ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ АҢЛАТМАЛЫ СҮЗЛЕГЕ

## VI том
## У–Я

Казан • 2021

УДК 811.512.145'374.3
ББК 81.2Тат-4
Т 23

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының
гыйльми советы карары нигезендә басыла*

«2014–2022 елларда Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында нәшер ителә

*Россия Федерациясенең авторлык хокукы һәм эргәдәш хокуклар турындагы законнары белән саклана (РФ ГК, 4 өлеш). Китапны тулысы белән яки өлешчә, төрле, шул исәптән электрон мәгълүмат чыганакларына урнаштыру авторлык хокукына ия юридик затның язма рөхсәтеннән башка катгый тыела*

**Проект җитәкчесе –** Р.Т. Сәфәров

**Төзүче авторлар:**

И.И. Сабитова, Ф.Ф. Гаффарова, О.Н. Галимова, Э.И. Сафина, Ә.К. Булатова, А.Ә. Тимерханов, Ф.А. Кушелекова, И.Җ. Едиханов, Ф.И. Таһирова, Р.Т. Сәфәров

**Фәнни редакторлар:**

Ф.И. Таһирова, Р.Т. Сәфәров

**Бәяләүчеләр:**

*Казан (Идел буе) федераль университеты Алабуга институтының татар филологиясе кафедрасы* (мөдире – Р.Б. Камаева, филология фәннәре докторы, доцент)

*М. Акмулла исем. Башкорт дәүләт педагогика университеты Филологик белем бирү һәм мәдәниятара багланышлар институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы* (мөдире – И.С. Насипов, филология фәннәре докторы, доцент)

**Т 23** **Татар теленең аңлатмалы сүзлеге:** VI том: У – Я. – Казан: ТӘһСИ, 2021. – 912 б.
ISBN 978-5-93091-394-1

Татар теленең күптомлы фундаменталь аңлатмалы сүзлеге – күләме һәм эчтәлеге белән мондый төр сүзлекләрдән иң тулысы. Ул татар тел белеме, тюркология һәм гомуми лексикографиянең ирешкән уңышларын, уңай тәҗрибәсен исәпкә алып төзелде.

VI томда барлыгы 14 меңгә якын сүз һәм 1 500 дән артык фразеологик берәмлек теркәлде. Төп фигыль оясында мәгънә төсмерләренә ия булган тезмә фигыльләр дә кертелде. Сүзлек хәзерге татар әдәби теленең киң кулланышта йөргән актуаль лексикасы һәм фразеологиясеннән, төрле фән һәм хуҗалык тармакларына караган термин, атамалардан гыйбарәт. Анда соңгы вакытта татар теленең үз чаралары белән ясалган неологизмнар, кабат активлашкан сүзләр, телне баетырдай диалектизмнар, алынмалар да чагылыш тапты.

Сүзлек киң катлау укучыларга, шулай ук төрле фән белгечләренә гамәли кулланма буларак тәкъдим ителә.

**ISBN 978-5-93091-394-1**

© ТФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ, 2021

# СҮЗ БАШЫ

Татар теленең күптомлы фундаменталь аңлатмалы сүзлегенең I томына А–В, II томына Г–Й, III томына К, IV томына Л–Р, V томына С–Т хәрефенә башланган сүзләр кертелде. VI том У–Я хәрефләренә башланган сүзләрдән тора. Сүзлеккә кагылышлы белешмә материаллар тулы рәвештә I томда бирелде.

Проектның гомуми координаторы һәм җитәкчесе – Р.Т. Сәфәров.

Сүзлекнең VI томын төзүдә түбәндәге хезмәткәрләр катнашты: И.Җ. Едиханов – У хәрефе (у – урман); Ф.А. Кушелекова – У хәрефе (урман-дала – уңылдашу); Һ хәрефе (тулысынча); А.Ә. Тимерханов – Ү хәрефе (тулысынча); Я хәрефе (ямансулык – ярма); Ф.Ф. Гаффарова – Ф хәрефе (тулысынча); Ы хәрефе (тулысынча); Ю хәрефе (тулысынча); Я хәрефе (ярмалану – яулыклык); Э.И. Сафина – Х хәрефе (тулысынча); Я хәрефе (я – ямансулау); Р.Т. Сәфәров – Ц хәрефе (тулысынча); О.Н. Галимова – Ч хәрефе (чаба – чутлау II); Ә.К. Булатова – Ч хәрефе (чутсыз – чүңкәю); Щ хәрефе (тулысынча); Я хәрефе (яулыкчан – яһүди); Ф.И. Таһирова – Ш хәрефе (шабаш – шатландыру); И.И. Сабитова – Ш хәрефе (шатлану – шүрәле); Э хәрефе (тулысынча).

Сүзлек материалы элекке алфавит тәртибендә бүленде, соңыннан хәзерге алфавитка туры китереп урнаштырылды.

Сүзлекнең VI томын Ф.И. Таһирова һәм Р.Т. Сәфәров һәр икесе тулысынча редакцияләде.

Томны туплау, материалларны берләштереп, алфавитка салу эшен Р.Т. Сәфәров башкарды.

Авторларның исемнәрен албиттә күрсәтү тәртибе аларның сүзлек төзүгә керткән өлешләрен исәпкә алып билгеләнде.

Хезмәтнең һәр томы электрон форматта http://antat.ru/ru/iyli/publishing/book/ адресы буенча урнаштырылган. Онлайн режимда томнардагы материалдан «Сүзлекләрнең электрон фонды» аша файдаланырга мөмкин (http://suzlek.antat.ru/index.php).

Сүзлекнең эшләнешенә, эчтәлегенә бәйле фикер һәм теләк-тәкъдимнәрегезне түбәндәге адреска юллый аласыз:

420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12 йорт
ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты.
Электрон адрес: iyali.anrt@mail.ru.

# СҮЗЛЕКТӘН ФАЙДАЛАНУЧЫЛАР ӨЧЕН БЕЛЕШМӘ

## I. Сүзлеккә сүзләр алу тәртибе

§ 1. Сүзлекнең нигезен хәзерге әдәби тел сүзләре һәм фразеологик берәмлекләре тәшкил итә.

§ 2. Сүзлеккә түбәндәге төркем сүзләр дә кертелде:

а) урта мәктәп һәм югары уку йортлары дәреслекләрендә очраган төп төшенчәләрне белдергән сүзләр (**БА́ЗИС, БАКТЕ́РИЯ, ТИГЕЗЛӘМӘ, ФО́РМУЛА** һ.б.);

ә) газета-журналларда урын алган күпчелек иҗтимагый-сәяси терминнар (**ДОТА́ЦИЯ, ВӘКАЛӘТ, РЕФЕРЕ́НДУМ, РЕЙД** һ.б.);

б) моңа кадәр басылып чыккан лексик минимумнарда һәм терминологик сүзлекләрдә тәкъдим ителгән аерым терминнар яки аларның тәрҗемәләренең шактый күләме (**АСТӨШЕРМӘ, БАШЛАМ, БИЗӘМ, ӨЛГЕ, ТАМГАХАНӘ, ТЕРКӘ́Ү** һ.б.);

в) бүгенге көн өчен яңа булган, вазгыятьнең үзгәрүе белән килеп кергән, язма әдәбиятның барлык төрләрендә дә очраган европа телләреннән алынган сүзләр (**БА́ЙКЕР, БАЙТ, БО́НУС, ДИВИДЕНД, ДИ́ЛЕР, ИПОТЕ́КА** һ.б.);

г) дингә, халык ышануларына, мифологиягә, йолаларга, төрле ырымнарга бәйләнешле сүзләр (**БАКЫЙ, БАПТИЗМ, БӘДӘЛ, БӘРМӘНЧЕК, НАРДУГАН, ФАНИ** һ.б.);

д) яңадан кулланышка актив кереп бара торган, телдә кабат торгызылган искергән сүзләр (**БАГАВЫЛ, БАЕК, БАЙСА, БАЛГА** һ.б.);

е) хәзерге чорда активлашкан һәм урта мәктәп, югары уку йортларында өйрәнелә торган борынгы әдәбиятта очраган гарәп һәм фарсы телләреннән кергән шактый алынма сүзләр (**БАБ, БАГБАН, БАЗАРКЯН, ҖӘНҮБ, ИГАНӘ, ИГЪДАДИ, ИГЪТИБА́РӘН** һ.б.);

ё) тарихи фактларны һәм элекке тормыш-көнкүрешне чагылдырган искергән сүзләр (**ӘДЕРНӘ, БАРЫМТА, БАТМАН, БАТРАК, БИЗМӘН, КАБИЛӘ, КАХАН, КАХАНЛЫК, НӨГӘР** һ.б.);

ж) әдәбиятта еш очраган һәм, киң кулланышка кереп, әдәби телне баетырдай дип табылган диалекталь сүзләр (**ӘНӘЧӘ, БАДЪЯН, БАШБАТА, КАБЫГУ, КАЗЫМА, ШАМА** һ.б.);

җ) матур әдәбият әсәрләрендә очраган яки хәзерге әдәби телдә еш кулланыла торган гади сөйләм сүзләре (**БӘЛШӘЮ, БӘРГӘЛӘШ, БЕЛӘМӘН** һ.б.);

з) киң кулланышка кергән яңа реалияләрне белдерү өчен, телнең үз җирлегендә ясалган яки мәгънәләре киңәйгән яңа сүзләр (**БАКЫЙЛЫК, БАРЛАМА, БАСМАК, ИГАНӘЧЕ, КОЛАКСА, КЕРТЕМ, ЭШМӘКӘР** һ.б.).

§ 3. Сүзлек берәмлеге итеп барлык грамматик сүз төркемнәренә дә караган сүзләр алынды. Конверсия юлы белән барлыкка килгән сүзләр һәм аларның мәгънәләре төп сүз мәкаләсендә күрсәтелде.

**ӘВӘРӘ** *и. фар.* **1.** Бик буталчык хәлләр, вакыйгалар. *Аның ул әвәрәгә ничек катнашып китүен һич аңлап та булмый, юкса иреккә чыгарына да нибары өч ай гына калган булган.* Казан утлары

**2.** *хәб. мәгъ.* Бер нәрсәгә бирелеп китү, мавыгу. *Нинди эшкә башың әвәрә?* Н.Исәнбәт

§ 4. Мөстәкыйль сүзлек берәмлеге буларак, тамыр сүзләр белән беррәттән, барлык сүз төркемнәренә дә караган төрле типтагы ясалма сүзләр дә кертелде. Шул исәптән: а) кушымчалау юлы белән ясалган сүзләр (**ӘЙЛӘНЕШ, ВӘКАРЬЛЕК, ҖӘМӘГАТЬЧЕЛЕК** һ.б.); ә) саф кушма сүзләр (**АМПЕРМЕТР, АРПАБАШ**, **АЯ́ГҮРӘ, БАШКИСӘР** һ.б.); б) кыскартылган кушма сүзләр (**БАТРАЧКОМ, БЕНЗОВОЗ, РАБФАК** һ.б.); в) парлы сүзләр (**АНДА́-МОНДА, БАШ-АЯК**, **КҮРШЕ́-КҮЛӘН, САВЫТ-САБА** һ.б.); г) компонентлары аерым язылса да, кушма һәм тезмә сүзләр (**БАКА́ ЕФӘГЕ**, **БАКА́ ЯФРАГЫ**, **БАЛА́Н БАРМАК, БАСЫМЧА́К ИТҮ, ВАСЫЯ́ТЬ КЫЛУ, КЫШТЫ́Р-КЫШТЫР ИТҮ** һ.б.).

§ 5. Киң кулланышлы һәм продуктив булган алкушымчалар, шулай ук кушма сүзләрнең беренче яки икенче кисәкләре сүзлектә аерым мәкалә итеп бирелде (**АВИА-, АВТО-, АГРО-, -АРА, БИ-, БИО-, НЕО-, -СЫМАННАР** һ.б.).

§ 6. Сүзлектә түбәндәге сүзләр бирелмәде: а) үтә профессиональ сүзләр, ягъни фәннең һәм техниканың тик аерым тармакларында гына белгечләр тарафыннан кулланыла торган сүзләр; ә) әдәби телне баетмый һәм әдәбиятта гомумән очрамый торган җирле сөйләм сүзләре (диалекталь сүзләр); б) тупас сөйләм сүзләре, жаргон сүзләр; в) хәрефләрдән һәм авазлардан торган кыскартылма сүзләр; г) ялгызлык исемнәре.

## II. Сүзлекнең төзелеше

§ 7. Сүзлектә баш сүзләр алфавит тәртибендә урнаштырылды, һәм алар үзләренә караган материал (аңлатмалар, мисаллар, фразеологик берәмлекләр) белән бергә сүзлек мәкаләсен тәшкил итә.

§ 8. Баш сүздән соң аның сүз төркемен, чыганак телен, стилистик үзенчәлекләрен сыйфатлый торган билгеләре куелды. Шуннан соң мәгънәгә аңлатма бирелде, иллюстратив материал китерелде. Сүзнең барлык мәгънәләрен дә ачып бетергәннән соң, кызыл юлдан шул сүз белән башланган фразеологик берәмлекләр теркәлде.

§ 9. Башка сүз төркеменә күчеп ясалган сүзләр нокталы калын, ә аларның мәгънәләре җәяле калын булмаган гади гарәп цифрлары белән аерылды.

**ИКМӘК** *и.* **1.** 1) Ачытылган камырдан мичтә пешерелгән ризык; ипи. *Икмәк – гомер, тазалык, мәхәббәт чыганагы, бәхет китерә торган өстәлдәге кояш ул.* А.Гыйләҗев...

2) Ашлык. *Гектарыннан утыз, кырык центнер алган хуҗалык күп булды. Колхоз ындырларында икмәк таулары ясалды.* М.Мәһдиев...

3) Кырда үсеп утырган иген. *Болгарларның җирләрендә бодай, арпа, тары һәм башка төрле икмәк тә үскән.* Г.Гобәйдуллин...

**2.** *ы. мәгъ. сөйл. к.* **икмәктер**. *Конкурста мин беренче урынны алам, Гөлүсә. Чын, икмәк!* Н.Гыйматдинова...

§ 10. Һәр мәгънә кызыл юлдан башланып китте. Сүзнең якынрак мәгънә төсмерләре параллель сызыклар (//), ә тагы да якын мәгънәләре нокталы өтер (;) ярдәмендә аерып күрсәтелде.

**ӘДӘП** *и. гар.* 1) Җәмгыятьтә гомумкабул ителгән әхлак кагыйдәләре; яхшы гадәтләр... // Кеше арасында үз-үзеңне әхлак кагыйдәләренә туры китереп тота белү с ыйфаты...

2) Яхшы гадәт, йола...

**АРКАДАШ** *и.* **1.** Иптәш, дус; таяныч. *Иске белешләр кебек, мәктәп аркадашлары кебек дуслашканнар иде.* Г.Исхакый...

§ 11. Тигез хокуклы грамматик һәм фонетик вариантлар мөстәкыйль сүзлек берәмлекләре итеп алындылар һәм һәркайсы алфавит тәртибендә үз урынында бирелде.

**АСТРОЛЯБ** *и. гр. сөйл. к.* **астролябия**. *Бер якта астролябка таянган Әбелхарис күренә. --- Әбелхарис астролябын тоткан килеш катып кала*. Н.Исәнбәт

**АСТРОЛЯ́БИЯ** *и. гр.* Астрономиядә: озынлык һәм киңлекне, шулай ук җир үлчәү эшләрендә горизонталь почмакларны билгели торган почмак үлчәү әсбабы.

§ 12. Компонентлары аерым язылган, лексик берәмлек тәшкил иткән кушма һәм тезмә сүзләр дә аерым сүзлек мәкаләсе итеп китерелде, сүзлектә алфавит тәртибендә урнаштырылды һәм аңлатылды.

**ӘҖЕ́-ГӨҖЕ КИЛҮ** *ф.* Озак итеп, дусларча сөйләшү...

**ИГЕ́Н ГӨМБӘСЕ** *и. а.х.* Ашлык бөртекләрен зарарлап, кара тузанга яки кибәккә әйләндерә торган гөмбә авыруы; корымбаш; *русчасы*: **головня.**

§ 13. Омонимнар шулай ук һәрберсе аерым мөстәкыйль сүзлек берәмлеге итеп алынды һәм калын булмаган рим цифрлары белән күрсәтелде.

**БИК** I *и.* 1) *иск. кит. к.* **би**

2) Морзалар нәселендәге фамилияләрдә һәм кайбер кушма исемнәрдә сакланган компонент: *Биктимер, Бикбулат, Ханбиков.*

**БИК** II *и.* 1) Бикләп кую җайланмасы; йозак, келә, бастырык, бикләвеч. *Егетнең җавап сүзен дә көтмәстән, кортка, кискен хәрәкәтләр белән, ишеккә аркылы бик тә салып куйды.* Я.Зәнкиев…

**БИК** III *рәв.* **1.** 1) Гаять, көчле дәрәҗәдә, гадәттән тыш, чиктән ашкан, югары дәрәҗәдә, искиткеч, искитмәле. *Хатын, акча күп чыкмаганлыгы өчен мин дә бик шатланам.* Г.Камал. *Кәрим бай, Кәрим бай! Эшең хәзер бик уңай!* Т. Гыйззәт…

## III. Сүзләрнең мәгънәләрен билгеләү һәм аларны аңлату

*Мәгънәләрне алу һәм урнаштыру тәртибе*

§ 14. Сүзлектә китерелгән һәр тел берәмлегенең хәзерге әдәби телдә кулланылган барлык мәгънәләре дә аерып күрсәтелде.

§ 15. Алынма сүзләрнең бары тик татар телендә кулланылган мәгънәләре генә китерелде.

§ 16. Күпмәгънәле сүзләрне шәрехләгәндә, аның бөтен семантик кыры исәпкә алынып, аерым мәгънәләре билгеле бер тәртиптә урнаштырылды:

а) мәгънәләрнең бирелеш тәртибе беренче чиратта аларның хәзерге әдәби телдәге кулланыш ешлыгыннан чыгып билгеләнде; мәгънәләр логик эзлеклелекне һәм генетик бәйләнешне мөмкин кадәр сакларга тырышып урнаштырылды;

ә) мәгънәләрнең үсеш-үзгәрешендәге тарихи эзлеклелекне хәзерге тел материаллары ачык күрсәтеп торганда, сүзнең мәгънә төзелешен аңлауны җиңеләйтерлек очракларда, беренчел мәгънәләр, искергән булса да, алдан бирелде. Калган барлык очракларда искергән мәгънә, кагыйдә буларак, хәзерге мәгънәләрдән соң гына теркәлде;

б) конкрет мәгънәләр абстракт мәгънәләрдән алдарак урнаштырылды;

в) киң кулланыштагы мәгънәләр аның таррак кулланыштагы (гади сөйләм, диалекталь, терминологик һ.б. өчен хас булган) мәгънәләреннән алдарак китерелде;

г) диалекталь мәгънәләр гомуми һәм махсус кулланыштагы мәгънәләрдән соң теркәлде;

д) күчерелмә мәгънәләр туры мәгънәләрдән соң бирелде;

е) бер үк стилистик төсмергә ия булган мәгънәләрнең куллану ешлыгы югарырак булганы алданрак китерелде;

ё) сүзнең аерым синтаксик позициядә ачылган мәгънәләре төп мәгънәләрдән соң урнаштырылды.

**БА́ЙТАК** *рәв.* **1.** Шактый, шактый зур, шактый күп. *Кичкә таба өй тәмам туздырылып, аннары тау башындагы күрше авылга ташылып беткәч тә, капка һәм койма баганалары белән байтак изаландык әле без.* М.Вәли-Барҗылы...

**2.** *с. мәгъ.* Шактый санда булган, күп. *Инде байтак гомер яшәлгән, байтак һава суланган, су эчелгән, дөнья күрелгән дигән сүз.* Ф.Латыйфи...

**3. байтагы, байтагысы** *и. мәгъ. тарт. форм.* Зур өлеш, зур кисәк, зур төркем; бөтеннең зуррак өлеше. *Үрдәкләрнең байтагысы күл өстендә пыр итеп очтылар да түгәрәк ясап әйләнделәр.* Я.Зәнкиев...

ж) мөстәкыйль сүзнең ярдәмлек функциясендә кулланылган мәгънәсе (яки мәгънәләре) аның мөстәкыйль мәгънәләреннән соң бирелде.

**БӘРАБӘР** *с. фар.* **1.** Бердәй дәрәҗәдәге, тиң булган, лаек. *Үзенә бәрабәр ана арыслан белән юлдаш булып, сахрада күнды.* Дастан...

**2.** *рәв. мәгъ.* Бердәй, тиң. *Ә бит, чыдамлык белән сабырлык фатихага бәрабәр, дигән китап.* М.Хәсәнов

**3. бәрабәренә** *бәйл. функ.* Хакына, исәбенә. *Дөрес, без миллионнарның каны, җаны бәрабәренә, кеше гомере белән һич исәпләшеп тормастан, дөньядагы афәтләрнең берсен – фашизмны җиңеп чыктык.* А.Гыйләҗев...

§ 17. Конверсия юлы белән барлыкка килгән сүзләрдә ачылган мәгънәләр шул ук мәкалә эчендә төп мәгънәдән соң теркәлде.

**ЕЛДЫРЫМ** *и.* **1.** 1) Җәй көне арыш өлгергән вакытта кичләрен, төннәрен офык читендә күренә торган күкрәүсез яшен чаткысы; аҗаган. *Оренбург төбәгенең иркен дала ягы авылларында күк күкрәүсез ул яшен-елдырымны никтер «рәшә уйнау» дип атыйлар.* Л. Хәмидуллин...

2) *диал.* Яшен. --- *бөтен тирә-якны сызылып яктырткан елдырым балкышындагы төсле [күзаллады].* Т.Әйди...

3) Нинди дә булса утлар уйнау чагылышы. *Дөм караңгы төн, туплар гөрселди, офыкта утлар елдырымы чагылып китә, ә җирнең калтырап куйганын аяк табаннары гына сизә.* Х.Камалов...

4) *күч.* Берәр өлкәдә аз вакыт эчендә эз калдырган күренекле кеше. *Үзе дә әдәбият тарихында якты эз сызып, мәдәниятебез күгендә беренче рәшә, беренче елдырымнардан булган олы әдип Фатих Кәрими шагыйрь турында мондый сүзләр язып калдырган ---.* Л.Хәмидуллин...

5) *күч.* Көтмәгәндә һәм тиз арада булып алган нинди дә булса физик яки рухи халәт, психик күренеш. *Уттай кайнар елдырым аркасын пешереп узды.* Х.Камалов...

**2.** *с. мәгъ. күч.* Елгыр, җитез, өлгер; хәрәкәтчән. *Мин Зөһрә туташ белән сөйләштем. [Гарифҗан:] Сөйләштең? Елдырым егет икән син.* Н.Исәнбәт...

§ 18. Сүзнең тартымлы яки берәр кыек грамматик формасы өчен генә хас булган мәгънә (яки мәгънә төсмере) шул ук мәкалә эчендә әйтелгән грамматик формада гомуми кагыйдәләр нигезендә бирелде.

**СӨЕКЛЕ** *с. шигъ.* **1.** …

2) **сөеклем** *тарт. форм.* Сөеп, үз итеп, иркәләп атау, эндәшү, мөрәҗәгать итү сүзе. *Әмма, исемә төшкәч, хәзер дә оялып куям – аны күтәреп кергәндә, мин аңа нинди генә иркә сүзләр әйтмәдем: җаным, дидем, бәгырем, дидем, сөеклем минем, матурым минем, дидем...* А.Шамов

**БАГУ** I *ф.* **1**. 1) *диал.* Карау, күз карашын юнәлтү, күз салу. ...

**3**. **бак, ба́ксана** *ы. мәгъ.* «Кара син аны», «кара әле» мәгънәсендә, игътибар итәргә кирәклекне, гаҗәпкә калуны белдерә. *Баксана! Бөтен күлем айкала!* Н. Исәнбәт. *Гөлҗамал абыстай, ишеткәнең бармы әле, менә бу кем малаеннан, баксана, аты коргыры, үләме әллә югыйсә...* М. Гали

**4. баксаң, бактың исә** *кер. сүз мәгъ.* 1) Чын-чынлап уйласаң, игътибар итсәң. *Баксаң, шунда бер матур кыз тынып калган.* Н.Исәнбәт. *Бакты исә, бер дә катлауландырасы юк, барысы да мөмкин икән.* Ф.Хөсни

2) Соңыннан билгеле булганча, чынлыкта, чынбарлыкта. *Бактың исә, «дөнья» дигән нәрсә ул бер генә түгел икән әле.* Ф.Фәизов...

§ 19. Алынма сүзләрнең мәгънәләрен бирү тәртибе татар телендә кулланылган мәгънәләренең үзара бәйләнешеннән чыгып билгеләнде.

**РАДИА́ТОР** *и. лат.* 1) Эчке янулы двигательләрне сыеклык ярдәмендә суыту җайланмасы. *Йөк машинасында йөрүче безнең бер шофёрның радиаторына ябалак бәрелгән булган.* Г.Әпсәләмов

2) Үзәктән ягып җылыту системасында пар яки кайнар су йөри торган торбаларга тоташтырылган җайланма.

*Мәгънәләргә аңлатма бирү тәртибе*

§ 20. Сүзлек берәмлеге итеп алынган барлык гади, кушма һәм тезмә сүзләрнең һәм фразеологик гыйбарәләрнең мәгънәләренә һәм мәгънә төсмерләренә тиешле аңлатма бирелде.

§ 21. Аңлатмалар стилистик яктан нейтраль, туры мәгънәдәге һәм гомуми кулланыштагы сүзләр ярдәмендә генә төзелде. Тар кулланышлы (гади сөйләмгә караган, поэтик, диалекталь, махсус һ.б.), сирәк очрый торган искергән сүзләр яки сүзләрнең күчерелмә мәгънәләре, шулай ук бу сүзлеккә кермәгән сүзләр аңлатмаларда файдаланылмады.

§ 22. Сүзлектә, сүзнең мәгънәсен ачыклау өчен, аңлатмаларның өч төрле ысулы кулланылды:

1. Тасвирлаулы аңлатма. Сүзләрнең мәгънәсе һәм мәгънә төсмерләре күпчелек очракта кыскача аңлатма бирү юлы белән ачыкланды.

**ҖАМАЯК** *и.* Төрле зурлыкта һәм тирәнлектә булган тоткасыз савыт. *Карчыкның кулыннан агач җамаягы төшеп китеп, ат аягы астына тәгәрәде.* М.Галәү...

2. Синонимик аңлатма, ягъни сүзнең мәгънәсен ачу өчен, аның синонимын (синонимнарын) файдалану. Мондый аңлатмалар бигрәк тә нинди дә булса берәр стилистик төсмере булган (искергән, диалекталь, гади сөйләмгә караган һ.б.) сүзнең яки алынма сүзләрнең мәгънәсен ачу өчен кулланылды.

**ӘШТЕ́Р-ӨШТЕР** *рәв. сөйл.* Ашыгып, аннан-моннан, өстән-өстән генә...

3. Башка сүзгә яки аның аерым мәгънәсенә (мәгънәләренә) җибәрү. Бу ысул мәгънәләре охшаш яки бик нык якын булган сүзләрдә (синонимнарда) кулланылды. Төп аңлатма тиңдәшләренә караганда күбрәк кулланыла торган сүз янында бирелде, ә калганнарының мәгънәсе шул сүзгә җибәрү юлы белән аңлатылды.

**БАЛАШАР** *и. к.* **балимәр**

**БАЛИМӘР** *и.* Сайрар чыпчыклар семьялыгыннан тонык көрән яки яшел төстә, тел очында чәчәкләрнең баллы суын суырырга махсус щётка сыман әгъзасы булган кечкенә көньяк кошы; *русчасы*: **медосос**.

Күпмәгънәле сүзләргә яки омонимнарга җибәргән очракларда, сүзнең кайсы мәгънәсенә яки кайсы омонимга җибәрелүе күрсәтелде. Искәрмә буларак, сүзлекнең зур күләмле булуын исәпкә алып, икенче сүзнең мәгънәсенә җибәргәндә, ул сүз кергән томның басылып чыккан булу шарты куелды. Бу шартка туры килмәгән очракларда, сүзләр алда күрсәтелгән тәртиптә (нигездә, синонимын күрсәтү юлы белән) ачыкланды.

**КАЕРЫЛУ** *ф.* **1.** 1) *төш. юн. к.* **каеру**. *Урамга караган өч тәрәзәнең дә капкачлары каерылган.* Ә.Еники...

5) *к.* **каеру** (*5 мәгъ.*). *[Бригадир] Шофёрга читтән, икенче юлдан китәргә боерды, һәм бәйрәмчеләр төялгән машина бара торган юлыннан кырт кына читкә каерылды.* Н.Фәттах

§ 23. Сүзнең мәгънәсен тулырак ачыклау өчен, кайбер аңлатмаларда кулланылган өстәмә чаралар:

1. Әгәр сүзнең мәгънәсе тасвирлау юлы белән генә ачылып бетмәсә, аңлатмага өстәп, шул сүзнең синонимнары да китерелде.

**КАЗЫЙ** *и. гар. тар.* Шәригать законнарына нигезләнеп хөкем итүче рухани; хәким, судья. *[Хуҗа:] Өч сум өчен, минем йөземне ертып, казый әфәнде алдына килеп, тавыш күтәреп йөрергә оялмыйсыңмы*? Н.Исәнбәт

2. Аерым очракларда бирелгән сүзнең аңлатмасы аның капма-каршы мәгънәдәге сүзләре (антонимнары) белән дә тулыландырылды.

**ҖИҢЕЛЛЕК** *и.* 1) Авырлыгы аз булу; *киресе*: **авырлык**. *Җисми кагылу түгел, Мамык җиңеллеге белән Ачылып китте күгем.* Б.Рәхимова;

2) Уңайлы, җиңел булу; *киресе*: **авырлык, кыенлык**. *Һәр авырлыкның бер җиңеллеге бар.* Мәкаль...

3. Сирәк очракларда, бигрәк тә вариантлары күп булган, төрле сүзлекләрдә төрлечә бирелгән атамаларның русчага тәрҗемәләре дә китерелде.

**БАКА́ ТӘҢКӘСЕ** *и. бот.* Нәрсенчәләр семьялыгыннан вак яфраклы йөзмә су үсемлеге; нәрсен; *русчасы*: **ряска...**

4. Капма-каршы мәгънәдәге сүзләр (антонимнар) һәм тәрҗемәләр аңлатма ахырында нокталы өтер белән аерып бирелде.

**БАЙЛЫК** *и.* 1) ... ;

2) Җитешлек, муллык, иркенчелек; *киресе*: **ярлылык, мохтаҗлык.**

§ 24. Сүзнең телдә сирәгрәк кулланылган мәгънәләренә сылтамалар биргәндә, ул мәгънә җәя эчендә күрсәтелде.

**ВАФАСЫЗ** *с.* **1.** *иск. кит.* Тугрылыксыз, хыянәтчел, былагай (*1 мәгъ.*)...

§ 25. Сүзләрнең индивидуаль, метафорик, шигъри мәгънәләренә, шулай ук чагыштыруларда очрый торган мәгънәләренә аңлатмалар бирелмәде. Сүзләрдәге мондый мәгънәләр аерым очракларда мисалларда гына күрсәтелеп кителде.

### IV. Иллюстратив материалны бирү тәртибе

§ 26. Сүзләрнең мәгънәләренә аңлатмалар биргәннән соң, аерым очракларны исәпкә алмаганда, иллюстратив материал белән ныгытып барылды.

§ 27. Иллюстрация өчен китерелгән мисаллар күбесенчә татар телендә басылган матур әдәбияттан, иҗтимагыйсәяси, публицистик, фәнни-популяр, фольклор әсәрләреннән, дәреслекләрдән һәм вакытлы матбугаттан алынды.

§ 28. Мисалга китерелгән җөмләләр артык озын булган очракта, мәгънәгә зыян китермичә, кыскартулар ясалды. Сүзләр төшеп калган урыннар өч сызыкча (---) белән күрсәтелде.

**ӘБИ́-БАБА(Й)** *җый. и.* 1) ... ; 2) ...

3) Борынгылар, өлкән буын кешеләре. *Бу китапны укып, мәктәп балалары --- хәтта ике-өч буын әби-бабалары да белмәгән, ишетмәгән вакыйгалар --- дәрьясына чумачаклар.* Р.Әмирхан

§ 29. Китерелгән мисаллардагы алмашлык алыштырган сүз, эш-хәрәкәтнең кем тарафыннан башкарылуы, репликаның кемгә төбәлгән булуы яки кем тарафыннан әйтелүе яисә алдагы җөмләләрдән аңлашылып, әйтелми калган сүз квадрат җәяләр эчендә искәрмәләр рәвешендә биреп барылды.

**БӘЙЛӘВЕЧ** *и.* 1) Бербөтеннең очларын, ян-якларын (мәс., изүне, балак очларын һ.б.) тоташтыру, бәйләү өчен кара-каршы тагылган бауларның берсе. *Ул [лейтенант], сөйләшү тәмам дигән шикелле, папкаларын ябып, бәйләвечләрен бәйли башлады.* Х.Камал...

**БИКЛЕ** *с.* 1) Йозак белән бикләнгән; нәрсә белән дә булса керә алмаслык итеп ябылган, йозакланган. *Капка бикле иде, [Камали] авыр гәүдәсе белән ятып, күпме этәрсә дә ачылмады.* К.Нәҗми...

**ӘЙТЕШҮ** *ф.* 1) ... ;

2) Гаепләшү, тиргәшү, ачуланышу. *Ачуланышмыйлар, әйтешмиләр дә, шул ук вакытта ачылып сөйләшмиләр дә иде [каенана белән килен].* М.Маликова...

§ 30. Һәр җөмлә янында чыганакның авторы күрсәтелде.

§ 31. Аерым очракларда мисал итеп сүз тезмәләре яки кыска җөмләләр дә китерелде.

**АБАЙСЫЗ** *рәв. сөйл.* Саксызлык, гамьсезлек күрсәтеп, хафасыз; таркау. *Ничектер бу Гөлбикә күңелдәге изге бер нәрсәгә абайсыз, дорфа рәвештә кагыла иде.* А.Расих…

**БУР** I *и. сөйл.* Ак төстәге йомшак известь. *Балалар бур белән асфальтка рәсем ясый.*

### V. Алынма сүзләрнең чыганак телен күрсәтү тәртибе

§ 32. Тел хәзинәсендә чит (рус, гарәп, фарсы, фин-угор һ.б.) телләрдән турыдан-туры кучкән алынма сүзләр бар. Алар – татар халкының күп гасырлар буена бу халыклар белән якыннан аралашып яшәве нәтиҗәсе. Борынгы алынмалар, фонетик һәм морфологик үзләшеп, татар теле грамматикасына тулысынча буйсынганнар, аның үз сүзләренә якынайганнар. Хәзерге тел хәлендә бу алынма сүзләрне аерып алу гади кулланучыга мөмкин дә булмас иде.

§ 33. Татар телендә шулай ук европа телләреннән алынган сүзләр дә бар. Алар, нигездә, хәзерге чорда рус теле аша күчкән сүзләр. Сүзлектә мондый сүзләрнең беренчел чыганагы – европа телләре күрсәтелде.

Сүзлек массакүләм белешмәлек булганлыктан, сүз турында мәгълүмат алу өчен, барлык алынма сүзләрнең чыганак телен күрсәтү кирәк дип табылды.

### VI. Сүз төркемнәренең бирелеше

§ 34. Сүзлек берәмлеге буларак барлык төр сүз төркемнәре дә алынды. Баш сүзнең кайсы сүз төркеменә каравы грамматик билгеләр белән күрсәтелде: *и.* (исем), *ф.* (фигыль), *с.* (сыйфат), *а.* (алмашлык), *сан* (сан), *рәв.* (рәвеш), *бәйл.* (бәйлек), *терк.* (теркәгеч), *кис.* (кисәкчә), *ы.* (ымлык), *иярт.* (ияртем), *хәб. сүз* (хәбәрлек сүз), *мод. сүз* (модаль сүз).

§ 35. Исемнәр сүзлектә берлек санда, баш килештә китерелде һәм *и.* грамматик билгесе белән аерымланды.

§ 36. Җыйма мәгънәдәге парлы исемнәр сүзлек берәмлеге буларак китерелде һәм *җый. и.* грамматик билгесе белән аерымланды.

**АЛЫ́Ш-БИРЕШ** *җый. и.* 1) Аласы һәм бирәсе әйбер(ләр); алачак һәм бирәчәк нәрсә(ләр)...

2) Сәүдә, сату-алу эше, кәсебе...

**ӘЙБЕ́Р-КАРА** *җый. и.* Төрле кирәк-яраклар...

§ 37. Ялгызлык исемнәренең, күмәклек мәгънәсе алып, киң кулланышка кереп киткәннәре сүзлектә китерелде (**А́МПЕР, ӘБҮҖӘҺЕЛ, ГАЗРАИЛ, ГАЙДАМАК, ГАЙДУК, ДӘҖҖАЛ, ИБЛИС, МА́УЗЕР, ОМ** һ.б.).

§ 38. Урта мәктәп дәреслекләрендә һәм матбугатта еш очрый торган төрле ил халыкларының һәм милләтләренең исемнәре чикләнгән күләмдә китерелде (**АБХАЗ, АВАР, АВСТРА́ЛИЯЛЕ, А́ВСТРИЯЛЕ, АЗӘРБАЙҖАН, АЛБАН, ӘРМӘН, ӘФГАН, БАЛКАР, БАШКОРТ, БОЛГАР** һ.б.).

§ 39. Исемләшкән исем һәм сыйфат фигыльләр (**АВЫРУ, АСРА́У, БЕЛДЕРҮ, ЧӘЧҮ, САТУ, ӘЙДӘҮЧЕ, БИЮЧЕ, ОЕШТЫРУЧЫ, УКУЧЫ** һ.б.), сыйфатлашкан сыйфат фигыль (**ЕЛАГАН, ЯРАТКАН** һ.б.), рәвешләшкән хәл фигыльләр (**БАГАНАЛАП, БАЛЛАП, БАТМАНЛАП, ЕЛЛАП, ИПЛӘП** һ.б.) аерым сүзлек мәкаләсе итеп алынды.

§ 40. Алмашлыклар *а.* грамматик билгесе белән аерымланды. Сүзлек мәкаләсендә зат алмашлыкларының һәм *ул, бу, шул* алмашлыкларының кыек килеш формалары да бирелде. Ул баш сүз артыннан гади җәя эчендә күрсәтелде. Сүзнең нигезе үзгәргән очраклар аерым сүзлек мәкаләсе итеп китерелде.

**МИН** (**минем, миңа, мине, миннән, миндә**) *а.* Сөйләүченең үзен атап күрсәтү өчен кулланыла торган беренче зат алмашлыгы.

**УЛ** II (**аның, аңа, аны, аннан, анда**) *а.* Өченче затны яисә гомумән предметны белдерә…

**АҢА** *а. Ул* алмашлыгының юнәлеш килеш формасы.

§ 41. Фигыльне сүзлектә бирү формасы итеп, төп юнәлештәге (*-у/-ү*) исем фигыль формасы алынды һәм *ф.* грамматик билгесе белән аерымланды (**АЛУ, ӘЙТҮ, ДИМЛӘ́Ү, ЗЫҢЛА́У, КҮЗӘТҮ, КАЙТУ, КӨЛҮ** һ.б.)

§ 42. Грамматик мәгънә белдерә торган фигыльләрнең саф юнәлеш формалары телнең грамматик төзелешенә карый, шунлыктан алар сүзлектә теркәлмәде.

§ 43. Лексик мәгънәгә ия булган фигыльләрнең юнәлеш формалары сүзлектә бирелде. Аларның беренче грамматик мәгънәсе төп формага җибәрү юлы белән күрсәтелде, ә лексик мәгънәсенә (мәгънәләренә) аңлатмалар китерелде.

**АШАЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **ашау** (*1 мәгъ.*). *Хәзрәтләр – шактый күп алган туй садакасыннан, авыл кешеләре – тәмле иттереп ашалган ашлардан, кода-кодагыйлар – яхшы бирнәләрдән, Садыйк абзый, Мәрфуга абыстай мәҗлеснең муллаларча затлы үтүеннән разый калдылар.* Г.Исхакый

2) Кояш, җил, су яки башка нәрсәләр тәэсиреннән бозылу, үзгәрү (йөз-кыяфәт, кием-салым һ.б.ш. тур.). *Җил-яңгыр белән калай түбәләренең буяулары ашалган, үзе җиргә сеңәргә әзерләнгән күн заводының корпуслары янынннан, култыкланып, Миләүшә елгасы ага.* А.Алиш

3) Кыршылу, кырылу, ышкылу, тузу. *Ботинканың ашалган үкчәләрен дә төзәткән иде ул.* А.Шамов

§ 44. Дәрәҗә белдерә торган тезмә фигыльләрнең телдә киң кулланылганнары, төп сүзгә аңлатма бирелгәч, фразеологизмнарны күрсәтеп бетергәннән соң, беренче сүз принцибы белән шул фигыль янында ояда алфавит тәртибендә теркәлде.

**БӘЙЛӘ́Ү** I *ф.* 1) ... ;

2) ...

◊ **Бәйләп тоту** Ирексезләү, көчләү.

**Бәйләп алу** Тиз генә бәйләү; бәйләгән булу.

**Бәйләп ату** Аннан-моннан, ничек кирәк шулай бәйләү.

**Бәйләп бару** Эзлекле рәвештә бәйләү; бер-бер артлы бәйләү.

**Бәйләп бетерү** Тулысынча бәйләү; бәйләү эшен төгәлләү.

**Бәйләп кую** Алдан бәйләп әзер итү; бәйләнгән хәлдә калдыру, бәйләнгән хәлдә тоту.

**Бәйләп ташлау** Тиз-тиз генә бәйләү.

**Бәйләп тору** Булган берсен, һәрберсен бәйләү; сөйләү моментында, әле бәйләү белән мәшгуль булу; һәрвакыт, гел бәйле итү.

**Бәйләп чыгу** Һәммәсен бер-бер артлы бәйләү; һәрберсен бәйләү.

**Бәйли бару** Һәммәсен тоташтан яки эзлекле рәвештә бер-бер артлы бәйләү.

**Бәйли башлау** Бәйләргә тотыну.

**Бәйли төшү** Тагын да кысыбрак, тыгызрак бәйләү.

§ 45. Сүзлектә тезмә фигыльләр ясый торган түбәндәге модификацияләүче фигыльләр (дәрәҗә фигыльләре) кулланылды: **алу, ату, бару, башлау, бетерү, бетү, бирү, җибәрү, җиткерү, җитү, йөрү, калу, карау, керү, килү, китү, кую, салу, ташлау, тору, төшү, узу, утыру, чыгару, чыгу, язу, яту.**

§ 46. Сыйфат фигыль һәм хәл фигыль формалары, грамматик категория буларак, сүзлектә аерым китерелми. Әмма кайбер вакытта алар төп фигыльдән үзгә сыйфат һәм рәвеш мәгънәләрен дә белдерергә мөмкин. Шундый аерым очракта гына алар вокабула итеп теркәлде һәм лексик мәгънәләре аңлатылды.

**ВАКЛАП** *рәв.* 1) Аз-азлап, өлешләп, өзек-өзек бүлгәләп. *Фәния, кисәк-кисәк, ваклап сөйләшә торган теле белән, зарланып та алырга өлгерде.* Ф.Яхин

2) Данәләп, берәмләп, берәрләп; килолап, граммлап. *Күгендә-түшәгендә чалкан яткан, ваклап сатучыларның кыланышына өйрәнгән айның да исе китми.* Т.Галиуллин. *Электр энергиясен күпләп сату базарының яңа кагыйдәләре кертелгәч һәм ваклап сату базары кагыйдәләре кабул ителгәч, энергия белән тәэмин итүче оешмалар һәм энергия кулланучылар арасында үзара бәйләнеш нык үзгәрәчәк.* Идел

3) Нечкәлекләренә төшенеп, җентекләп, төпченеп. *Кыздырып барган кояш нуры астында, ваклап, тармаклап, җиһаныньнең урынын сыйфатлап язды.* Г.Ибраһимов

**ВАКЛА́У** *ф.* 1) Вак-вак, кечкенә кисәкләргә, өлешләргә бүлгәләү, вату, тураклау, аеру; вак итү. *Койма буендагы такталарны, кисеп, утынга вакларга кирәк.* М. Мәһдиев. *Роторлы җайланманың җитешсезлеге – ул, гадәти барабанга караганда, саламны шактый күбрәк ваклый.* П. Макаров

2) Эре акчаны шул ук суммадагы вак акчага алмаштыру. *[Тәзкирә:] Соңгы егерме бишлекне вакларгамы?* А.Гыйләҗев...

§ 47. Татар телендә кайбер мөстәкыйль фигыльләр ярдәмче фигыль функциясендә йөри. Сүзлектә бу күренеш күрсәтелде.

**КИТҮ** I *ф.* **1.** 1) ... ; 2) ... .

**3.** *ярд. ф. функ.* 1) Хәл фигыльләрнең *-ып (-еп), -п* формасы белән бәйләнештә килеп, аларның төп мәгънәсенә түбәндәге төсмерләр өсти: 1) юнәлешле яки нәтиҗәле хәрәкәт төсмере (башлыча хәрәкәтне белдерә торган фигыльләр белән). *Ул иртә үк торып, эш булмас микән дип чыгып китте.* М.Гафури…

2) Үзеннән алдагы хәл фигыльдән аңлашылган сыйфатка күчү, шул сыйфатка ия булуны белдерә. *Әминә шунда ук, дәртләнеп китеп, Шәрәфкә хат язарга утырды.* Г.Минский…

3) Төп фигыльдән аңлашылган эшкә дәвамлылык төсмере өсти. *Аста, як-якта, ярга терәп салынган кара мунчалар тезелеп киткән.* Г.Гобәй

4) Эш-хәлнең тиз һәм интенсив башкарылуын аңлата. *Су өсте күз нурын алырдай булып, ялтырап, яктырып китте.* Х.Сарьян…

5) *Булып* ярдәмче фигыле белән килеп, эш-хәлнең дәвамлы төс алуын белдерә. *Ләкин көн дә шулай булып китсә, айлар буена шулай барса, мещан марҗалары синең мактануыңа эчтән кызганып, бичара дип карый башлаячаклар.* Г.Ибраһимов...

6) *шарт. ф. форм. -а/-ый* формалы хәл фигыль янында килеп, шул фигыльдән аңлашылган эш-хәлне дәвам иттерү мәгънәсен бирә. *Исәпли китсәң, бар да бер ноктага килеп җыела икән.* Казан утлары

## VII. Сүзнең басымын күрсәтү тәртибе

§ 48. Татар телендә басым күбесенчә сүзнең ахыргы иҗегенә төшә. Баш сүз булып килгән мондый очракларга (шул исәптән алынма сүзләргә дә) басым куелмады. Басым башка иҗекләргә төшкән очракларда гына, сүзнең басымы күрсәтелде.

**БАТЫРЛА́РЧА** *рәв.* ...
**Ю́ГЫЙСӘ** *тер.* ...
**ГИГИЕ́НА** *и.* ...

Бу кагыйдә омографларга да карый, әмма басымның кайда булуына карамастан, чагыштыру һәм дөрес уку өчен, басым икесенә дә куелды.

**КАРТА́** *и.* 1) Күшәүче хайваннар ашказанының алгы аерым өлеше. *Гаҗәп таныш ис аның [Габдулланың] борынын кытыклады: пешкән карта исе.* Ә.Фәйзи…

**КА́РТА** *и. фр.* 1) Җир өстенең яки күк йөзенең төзелешен шартлы билгеләр ярдәмендә сурәтләгән сызым; харита. *Тукай, географик карта алып, Бәләбәй шәһәренең Аксаково станциясеннән унөч кенә чакрымда урнашканлыгын белә.* Г.Мөрсәй…

§ 49. Татар телендә *-а / -ә* сузыкларыннан соң килгән *-у / -ү* авазлары сөйләмдә, кыскарып, ирен-ирен *в* [*w*] сонанты булып әйтелә, ә төзелмә үзе [*aw*] / [*әw*] тибындагы ялган дифтонг булып ишетелә, шул сәбәпле басым *-а /-ә* сузыкларына төшә. Бу очрак сүзлектә күрсәтелде.

**АБА́У** *ы.* ...
**АҢКА́У** II *и. анат.* ...
**БИКЛӘ́Ү** I *ф.* ...
**ВАКЛА́У** *ф.* ...
**ДӘ́Ү** *с. фар.* ...

## ШАРТЛЫ КЫСКАРТЫЛМАЛАР

*а.* – алмашлык
*авиа.* – авиация
*анат.* – анатомия
*антроп.* – антропология
*артык.* – артыклык (дәрәҗәсе)
*археол.* – археология
*архит.* – архитектура
*астр.* – астрономия
*а.х.* – авыл хуҗалыгы
*әд.* – әдәбият термины
*баш. кил.* – баш килеш
*бәйл.* – бәйлек
*бәйл. сүз* – бәйлек сүз
*берл.* – берлек сан
*биол.* – биология
*биохим.* – биохимия
*б-сез.* – билгесезлек
*бор.* – борынгы (сүз)
*бот.* – ботаника
*бүл. саны* – бүлем саны
*вет.* – ветеринария
*гади с.* – гади сөйләм
*геогр.* – география
*геод.* – геодезия
*геол.* – геология
*геом.* – геометрия
*грам.* – грамматика
*дәр.* – дәрәҗә
*диал.* – диалекталь сүз
*дини* – дини сүз
*диңгез.* – диңгезчелек термины
*жарг.* – жаргон
*җый. и.* – җыйма исем
*җыр* – халык җыры
*зоол.* – зоология
*з.-сыз* – затланышсыз (фигыль)
*и.* – исем
*икът.* – икътисад
*информ.* – информатика
*ирк.* – иркәләү сүзе
*ирон.* – ироник мәгънәдә
*иск.* – искергән сүз
*иял. кил.* – иялек килеше
*иярт.* – ияртем
*йөкл. юн.* – йөкләтү юнәлеше
*к.* – кара
*кбт. форм.* – кабатлаулы формада
*кайт. юн.* – кайтым юнәлеше
*карг.* – каргау (каргыш) сүзе
*кер. сүз* – кереш сүз
*кеч.* – кечерәйтү
*кил.* – килеш (формасында)
*ким.* – кимлек дәрәҗәсе
*кимс.* – кимсетеп әйтү
*кино* – кинематография
*кис.* – кисәкчә
*кит.* – китап теле
*комп.* – компьютер
*көч.* – көчәйтү
*кулин.* – кулинария термины
*күпл.* – күплек санда
*күрс.* – күрсәтү
*күч.* – күчерелмә мәгънәдә
*лингв.* – лингвистика
*лог.* – логика
*мат.* – математика
*махс.* – махсус термин
*мәгъ.* – мәгънәдә, мәгънәсендә
*мәс.* – мәсәлән
*мед.* – медицина
*метеор.* – метеорология
*минер.* – минерал яки минералогия
*миф.* – мифология
*мод. сүз* – модаль сүз
*мод. ф.* – модаль фигыль
*мөн.* – мөнәсәбәтле сүз
*муз.* – музыка
*мыск.* – мыскыллау сүзе
*неол.* – неологизм
*нәфр.* – нәфрәтләнү
*окказ.* – окказионализм
*пед.* – педагогика
*полигр.* – полиграфия
*психол.* – психология
*радио.* – радиотехника
*рәв.* – рәвеш
*рәсм.* – рәсми
*ритор.* – риторик
*с.* – сыйфат
*сан* – сан
*сәнг.* – сәнгать
*сәяси* – сәяси термин
*сир.* – сирәк кулланышта
*сөйл.* – сөйләм телендә
*спорт* – физкультура һәм спорт
*тар.* – тарихи
*тарт. форм.* – тартымлы формада
*тасв.* – тасвири сәнгать
*тәрт. саны* – тәртип саны
*театр* – театр сәнгатенә караган сүз
*терк.* – теркәгеч
*тех.* – техника термины
*типогр.* – типография термины
*тирг.* – тиргәү сүзе
*төзел.* – төзелеш термины
*төш. кил.* – төшем килеше
*төш. юн.* – төшем (юнәлеше)
*туп.* – тупас сүз
*тур.* – турында
*урт. юн.* – уртаклык (юнәлеше)
*у.-вак. кил.* – урын-вакыт килеше
*ф.* – фигыль
*фарм.* – фармацевтика
*физ.* – физика
*физиол.* – физиология
*филос.* – философия
*финанс.* – финанслар
*фольк.* – фольклор
*форм.* – формасында
*фото.* – фотография
*функ.* – функция
*хим.* – химия
*хуплм.* – хупламау
*хупл.* – хуплау
*хурл.* – хурлау
*хәб.* – хәбәр
*хәб. сүз* – хәбәрлек сүз
*хәрби* – хәрби сүз
*чаг.* – чагыштыру
*чыг. кил.* – чыгыш килеше
*шахм.* – шахмат
*шаярт.* – шаярту сүзе
*шелт.* – шелтәләү сүзе
*шигъ.* – шигъри сөйләмдә
*ы.* – ымлык
*эвф.* – эвфемизм
*энд.* – эндәш сүз
*электр.* – электротехника
*эпис.* – эпистоляр стиль
*этн.* – этнография
*юг.* – югары стиль
*юкл.* – юклык
*юн.* – юнәлеш
*юн. кил.* – юнәлеш килеше
*юр.* – юридик термин
*ялг.* – ялгыш куллану варианты
*ярд.* – ярдәмче (фигыль яки сүз)

## Чыганак телләрнең кыскартылмалары

*алб.* – албан теле
*амхар* – амхар теле
*афр.* – Африка телләре
*ацтек* – ацтек телләре
*әрм.* – әрмән теле
*баконго* – баконго теле
*бурят* – бурят теле
*венг.* – венгр теле
*гар.* – гарәп теле
*герм.* – герман телләре
*голл.* – голланд теле
*гр.* – грек теле
*груз.* – грузин теле
*гуарани* – гуарани теле
*ингл.* – инглиз теле
*исланд* – исланд теле
*исп.* – испан теле
*ит.* – итальян теле
*ительмен* – ительмен теле
*кельт* – кельт теле
*кечуа* – кечуа индеецлары теле
*коми* – коми теле
*кыт.* – кытай теле
*лат.* – латин теле
*литв.* – литва теле
*малай* – малай теле
*малаял.* – малаялам теле
*мар.* – мари теле
*монг.* – монгол теле
*мордв.* – мордва теле
*нем.* – немец теле
*норв.* – норвегия теле
*пол.* – поляк теле
*полинез.* – полинезия телләре
*португ.* – португал теле
*румын* – румын теле
*рус* – рус теле
*саам* – саам теле
*санскр.* – санскрит теле
*сканд.*– скандинав телләре
*слав.* – славян телләре
*сугд* – сугд теле
*тамил* – тамил теле
*тат.* – татар теле
*тибет* – тибет теле
*төрек* – төрек теле
*төрки* – борынгы төрки сүз
*тунг.* – тунгус теле
*тупи* – тупи теле
*удм.* – удмурт теле
*уйг.* – уйгур теле
*укр.* – украин теле
*үзб.* – үзбәк теле
*фар.* – фарсы теле
*фин* – фин теле
*фин-угор* – фин-угор телләре
*фр.* – француз теле
*һинд.* – һинди теле
*чех.* – чех теле
*чук.* – чукча теле
*швед* – швед теле
*эвен* – эвен теле
*эвенк* – эвенк теле
*эст.* – эстон теле
*як.*– якут теле
*яп.* – япон теле
*яһүд* – яһүд теле

## ТАТАР АЛФАВИТЫ

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Аа | Дд | Зз | Мм | Пп | Үү | Чч | ь |
| Әә | Ее | Ии | Нн | Рр | Фф | Шш | Ээ |
| Бб | Ёё | Йй | ң | Сс | Хх | Щщ | Юю |
| Вв | Жж | Кк | Оо | Тт | Һһ | ъ | Яя |
| Гг | Җҗ | Лл | Өө | Уу | Цц | Ыы | |

# У

**У** I *иярт.* 1) Җил, су һ.б.ш.ның агымы берәр тоткарлыктан үткән вакытта чыккан тавышны, гүләп эшләгән механизм яки машиналар чыгарган тоташ шауны белдерә. *Колак салып торсаң, тонык буа шаулавы аша вакыт-вакыт ерактагы молотилканың ууу... ууу дип үкереп куйганы ишетелеп кала.* Ә.Еники

2) Хайван үкергәндә, улаганда чыккан тавышны белдерә. *Шулчак алпан-тилпән басып, үзенчә бик яман ярсып, янгын чыккан дип белеп, аю килә үкереп: – Ууу, – ди, – ууу!* Р.Вәлиева

**У** II *ы.* 1) Куркыту, шелтә, кисәтү, янау, ачу, нәфрәт һ.б.ш. хисләрне белдерә. *[Мәһирә ачуланып:] Ууу... бирән!* М.Җәлил. *Һашимовны әйтәм... У-у, нинди үзсүзле, каты күңелле кеше ул!* А.Вергазов

2) Курку хисен белдерә. *Уууу... нинди суык. Килеп җиткәнче кулларым өзелеп төшә язды...* И.Салахов. *Имәнлек чокыры язгы өеккә чыккан ач бүреләрнең янып ялтыраган күзләре белән кайнап тора!.. У-у-у, исләренә төшсә, тәннәре өшеп китә!..* А.Хәлим

3) Хуплау, гаҗәпләнү, соклану һ.б. хисләрне белдерә. *Аннан борын яфракларын чак кына киереп, һаваны иснәгәндәй (артист та икән әле үзе) итте дә: – У-у, итле аш пешерәсез, уңган икәнсез[– диде].* Б.Рәхимова

**УА** *и. иск. к.* **рахит**. *Аякларына уа булган өстенә, ятса, арт санын җирдән күтәрә алмый.* З.Зәйнуллин

**УАЛАНУ** *ф. сөйл.* 1) Уалу, ваклану, вак-вак хәлгә килү. *Сохари капчык төбендә уаланган*

2) *күч.* Борчылу, кайгырып бәргәләнү. *Әлбәттә, бөтен Россия кризис дип уаланганда, министрлыкның шундый нәфес күрсәтүе, беренче карашка, күремсезлек кебек күренә.* Ватаным Татарстан

**Уалана башлау** Уаланырга тотыну

**Уалана төшү** Бераз гына уалану; тагын уалану

**Уаланып бетү** Тәмам уалану

**Уаланып йөрү** Озак вакыт дәвамында уалану. *Шаярту-көлү түгел, көне буе йөз сытып уаланып йөрүең бар.* Кызыл таң

**Уаланып тору** Гел, һәрвакыт яки хәзерге моментта уалану; уалану үзлегенә ия булу. *«Җизни, нәрсә эшлим?» – дип уаланып тора.* Н.Кәримова

**Уаланып чыгу** Билгеле бер вакытның башыннан ахырына кадәр уалану. *Әти кыш буе уаланып чыкты: җитенкерәми хайванкайларга, комбикорм кайтармыйлар, бардага бармыйлар, печән-мазар да мыскаллап бирелә, анысы да такы-токы быел, диде...* А.Гыйләҗев

**УАЛА́У** *ф. к.* **угалау**. *– Чамала, үзеңә кала бит, мин ярты кеше генә, – диде ул, билен уалап.* Н.Кәримова. *Степан Васильевич, учы белән уалап, бәрәңгегә ябышкан көлне өреп очырды.* М.Юныс

**Уалап алу** Бераз гына уалау. *Өнемме бу, төшемме соң дигәндәй, чираттагы мәртәбә күзләрен уалап алды Җантимер.* Р.Мөхәммәдиев

**Уалый башлау** Уаларга тотыну

**УАЛУ** *ф.* 1) Бөтенлеген югалту, ярылу, кителү. *Чокыр идәнгә сабы белән бәрелеп уалды, һәм монысының тавышы беренчесенә бөтенләй охшамаган иде.* М.Хуҗин

2) Вак-вак кисәкләргә таркалу, ваклану, ватылу. *Европаны гизеп кайткан кырык бишле итек табаны астында тузанлы, иске күмерләр шыкырдап уалды.* М.Галиев

3) Вакыт үтү белән җил, яңгыр һ.б.ш. тәэсиреннән таркалу, җимерелү. *Бу нигезнең һәр уалган ташы Гүя өзелеп төшә йөрәктән.* М.Шиһапов. *Үткән гомер барыбер кире кайтмый, вакыты җиткәч, таш кыялар да уаладыр.* Ф.Мөслимова

4) *күч.* Юкка чыгу, җимерелү, булудан туктау (планнар, хыяллар тур.). *Шул таш сынга бәрелеп челпәрәмә килде, уалды аның өметләре.* Р.Мөхәммәдиев. *«Нык уй белән тутырылган» савытка ия герой куана, «тимердәй бәла»нең уалачагына өмете арткан-нан-арта бара.* Р.Әхмәтов

**Уала бару** Торган саен ныграк уалу. *Әмма соңгы көннәрдә бу өметемнең күзгә күренеп уала баруын сизү мине куркуга салды.* А.Әхмәтгалиева

**Уала башлау** Уалырга тотыну. *Җылымса иде балчык, уала башлаган иде, ә угланының каберенә бер уч балчык ташлаганда салкын тоелган иде, йөрәгенә кадәр суык йөгергән иде.* М.Хәбибуллин

**Уала төшү** Бераз уалу; тагын уалу

**Уалып бару** *к.* **уала бару**

**Уалып бетү** Тәмам уалу. *Нигезгә тезелгән кирпечләрең уалып беткән инде, почмакларың кыйшаеп бара.* Ф.Яруллин

**Уалып китү** Кинәт уалу. *Тимерләр чыдамаен уалып китте.* Н.Думави. *Бәгыре тишелеп, күңеле уалып китте.* Ф.Яхин

**Уалып тору** Уалу үзлегенә ия булу; хәзер уалу; гел, һәрвакыт уалу. *Таза ипиләр дә, солы, ясмык, борчак оны кушып пешергәнгә, вакланып, уалып торалар.* А.Гыйләҗев

**УАЛУЧАН** *с.* 1) Уала торган, таралып китү үзлегенә ия булган. *Кипкәч, ул бармак арасында уалучан коңгырт массага әйләнә.* А.Тимергалин. *Күп еллар буе ятып, шифер уалучанга әйләнгән.* Я.Шәфыйков

2) *күч.* Ныгып өлгермәгән, зәгыйфь һәм нәфис. *Әлбәттә, ул хәтта өмет тә түгел, ә болай гына, иркә кыз баланың бер мизгеллек җиңел һәм тиз уалучан матур хыялы гына булгандыр.* Р.Мирхәйдәров. *Шул ук вакытта һәркемнең бәллүр савыт кебек тиз ватылучан, чит куллар тиде исә уалучан эчке дөньясы, үз кабырчыгы бар.* Т.Галиуллин

**УАЛУЧАНЛЫК** *и.* Уалучан булу сыйфаты. *Хикмәт шунда: наратта металлның уалучанлыгын арттыра торган углерод бар, корымсыз янган каен исә аны чиста һәм бөгелүчән итә.* М.Зарипов

**УБА** *и. монг.* 1) Тирәсендәге тигез җирдән күтәрелеп торган кечерәк калкулык. *Бу киткәннән китмәсәм, Киң чүлләрне үтмәсәм, --- Кырык убага кырык басып, Яу булып килеп етмәсәм, --- Баба Түкләс бабам биргән Идегә атым корысын!* Дастан. *Тауга карап, тау булмассың, түмгәккә карап, уба булмассың.* Мәкаль. *Иксез-чиксез дала, уба-калкулыкларда кылган тибрәлә.* М.Мөсифуллин

2) *диал.* Җиргә казылып ясалган чокыр, җәнлек өне, кош оясы һ.б.ш. *Сак*

*атлап бар, төшә күрмә Бүреләр убасына.* М.Галиев. *Басып торган суыр янына ун адым калганчы барып була. Тагы да якынрак килә башласаң гына, «әнтыйф»ны кабатлап, койрыгы белән җиргә бәрә-бәрә, убасына кереп китә.* К.Рәхим

**УБЕ́ЖИЩЕ** *и. рус махс.* Кешеләрне ракета, авиация бомбалары, артиллерия снарядлары яки агулы матдәләрдән саклау максаты белән корылган сыенур урын. *Фашист самолётлары килгәндә, эшчеләр убежищега китмиләр, урыннарында калалар.* Г.Әпсәләмов. *Качар җир – убежищелар нәрсәгә ди миңа?* Р.Фәйзуллин

**УБУ** *ф.* 1) *к.* **убылу**. *Углан өчен таулар ишелде, җирләр упты, бозлар китте.* М.Хәбибуллин. *Ачкач ике-өч көн үтмәстән, асфальты кабат убып, бетон плитәләре кубып чыга.* Ф.Баттал

2) Үз эченә алу, йоту (җир, су тур.). *Эзлим сине, сине упкан сулар Дулкыннарын бәрә бәгырьгә.* Р.Әхмәтҗан. *Әгәр хәзер үк икебезне дә җир йотса? Шушында ук упса?* Х.Хәйруллин

3) *күч.* Тулысынча камап, каплап алу, үзенә алу. *Башкаларны чорнап алган кебек, берьюлы ук убып алмаса да, шулай да сугыш очкыны аларны да читтә калдырмады.* Ф.Хөсни. *Урап һәм убып алабыз, Кыеп алабыз җанын.* Н.Сафина

4) *күч.* Күп ашау, уру. *Әллә синең һич исең китмиме Зур-зур кабып икмәк убарга?* Г.Камал. *Каршына куйганны убу*

5) *күч.* Чамасыз күп тоту, сарыф итү, файдалану. *Килеп керәм сутлы балчыкка, үзәкләргә үтә, [машина] уба гына горючийны.* Г.Ахунов

**Уба башлау** Убарга тотыну. *Тыныч кына чәй эчеп утырганда яки йоклап ятканда җир уба башласа, өстеңә тонна-тонна таш яварга, шашлык кыздыргандагы кебек, астыңда ялкын телләре уйнарга керешсә, кая барып бәрелергә белмәссең, юләр!..* Безнең гәҗит

**Уба төшү** Бераз убу; тагын да убу

**Убып бетү** Беткәнче убу

**УБЫЛМА** *и. геогр.* Җир катлавы токымнарының үз авырлыгын тота алмыйча җимерелеп, ишелеп төшкән урыны. *Таулык көнбатыш яктан, көньяктан һәм аеруча көнчыгыштан убылмалар белән каймаланган, һәм ул чикләре кисеп алынган сыман текә битле массив булып тора ---.* Материклар һәм океаннар географиясе. *Белгечләрне борчыган тагын бер проблема убылмаларга бәйле.* Ватаным Татарстан

**УБЫЛУ** *ф.* Җир токымы яки боз катлавы, авырлыгын тоталмыйча, уелып, куышланып калган бушлыкка җимерелеп, ишелеп төшү. *Бәхетләре бар икән: ярга сикергән чакта, соңгы метрдагы боз убылды да, су бөтен елга өстенә ургыла башлады.* Г.Ахунов. *Ниндидер курку тойгысы аларны читкә куды, ләкин алар шундук түбәнәйделәр, шул мәлдә бер чите зур булып эчкә убылган чокырның авызына ук кереп киттеләр.* Ә.Гаффар

**Убыла бару** Әкрен генә, берөзлексез һаман убылу. *Шарлама чоңгылы киңәйгәннән-киңәйде, җир бушлыкка убылганнан-убыла барды, су кимеде.* Ә.Гаффар

**Убыла башлау** Убылырга тотыну. *Әмма берничә мәртәбә атуга, аяк астында җир убыла башлады.* Г.Гыйльманов

**Убыла төшү** Бераз гына убылу; тагын убылу

**Убылып алу** Кинәт кенә, бик тиз, бер тапкыр убылу. *Сабан туенда колга очына менеп җитеп бүләккә үреләм дигәндә генә кулы ычкынып киткән кебек, Каратаевның йөрәге убылып алды.* М.Галиев

**Убылып бару** *к.* **убыла бару**. *Чәчәкле аланның уртасы улы [Идегәй] белән бергә җир астына убылып бара.* Р.Туфитуллова

**Убылып бетү** Тәмам убылу. *Әйтүләренчә, утыз-кырык метр озынлыктагы, алты колач юанлыгындагы пәһлеван өянке, катлы-катлы итеп корылган карга оялары-ние белән бергә, упкынга тәмам убылып бетте.* Г.Гомәр

**Убылып калу** Ниндидер тәэсирдән соң убылган хәлгә килү. *– Бөтен теләгем: халкыма мөмкин кадәр күбрәк хезмәт күрсәтеп, үз-үземне аклау булды, – ди Сәләй ага. – Әсирлек, авыр сугыш еллары, тоткынлык еллары әнә шулай гомердән сызылып, убылып калды.* Р.Зарипов

**Убылып китү** Кинәт убылу; соңгы арада убылган хәлгә килү. *Зур коңгырт күзләре яшьләрчә саф күренсә дә, күз төпләре талчыккан кешенекедәй убылып киткән иде.* А.Вергазов. *Җир убылып китте.* Г.Гыйльманов

**Убылып кую** Бер тапкыр, бик тиз убылу. *Яр читеннән дүрт-биш тапкыр сикерергә өлгердеме-юкмы, аяк астындагы көпшәк кар тагы убылып куйды.* Р.Мөхәммәдиев

**Убылып тору** Һаман, әледән-әле убылу; убылган хәлдә булу. *Йортның базы булмаган, ахры, югыйсә баз урыны убылып торыр иде.* А.Тимергалин. *– Күпере юк, балалар басма аша йөри, җире убылып тора, аларны аннан йөртү куркыныч, – ди ата-аналарның берсе.* Ватаным Татарстан

**УБЫЛУЧАН** *с.* Ишелүчән, ишелергә торган. *Убылучан елга яры*

**УБЫР** *и. миф.* 1) Халык ышануларында кешеләрнең җаннарын алыштырып, уй-гамәлләре белән идарә итәргә сәләтле, ут булып йөри торган явыз мифик зат. *Җитмәсә, төрле хәшәрәтләр: албастылар, шүрәлеләр, диюләр, ялмавызлар, убырлар да бар, имеш.* Г.Гыйльманов. *Убырның кулында егетнең каныла манчылырга өлгергән коточкыч пычак, ә егеттә кыска гына, ләкин бик нык итеп эшләнгән табагач иде.* И.Хуҗин

2) *күч.* Чамасыз күп ашаучы, туймас тамак (кеше, хайван, кош-корт турында). *[Тәзкирә:] Сукага төшкән көн дип, шул сез убырларга бер яхшы аш ашатыйм, дидем.* Н.Фәттах. *Минем газиз балаларымның авызыннан өзеп алган хәрәм сый-нигъмәтләр ул убырның тамагына аркылы да тормый бит ичмасам!..* В.Имамов

3) Ачулану, тиргәү сүзе. *[Мәргупҗамал:] Убырлар, тәрәзә рамын каерып киткәннәр.* А.Гыйләҗев. *Эт үтереп алма урлап йөрисезме, убырлар?* Л.Ибраһим-Вәлиди

**УБЫ́Р ЗӘХМӘТЕ** *и. иск.* Бирән зәхмәте, шикәр авыруы

**УБЫ́Р КАРЧЫГЫ** *и. к.* **убырлы карчык**. *Хикәяләрдә сөйләнә торган убыр карчыгына охшаган куркыныч кайнананың ничек сөйләвен ишетер өчен торып китмәде, китә алмады.* Г.Исхакый. *Сине төрле аждаһа елannар, күз күрмәгән коточкыч ерткычлар, убыр карчыгы каршы алырлар.* А.Гадел

**УБЫ́Р КАРЧЫК** *и. к.* **убырлы карчык**. *Иртәгесен торгач, убыр карчык бу кызны мунча ягарга җибәрде.* К.Насыйри

**УБЫРЛЫ** *с.* Убыры булган, убыр ияләшкән. *Убырлы кеше баш түбәсеннән билгеле була – кечкенә генә бер чокыр сыман урын була, шуңа күрә андый кешегә: «Түбәсе тишек, бу убырлы икән», – диләр.* Мифологик хикәятләр. *– Болар убырлы кызлар иде, әйеме? – ди, ниһаять, пышылдап кына Альбина.* Кызыл таң

**УБЫРЛЫ́ ӘБИ** *и. к.* **убырлы карчык**. *Убырлы әби сине өр-яңадан туганга чутлый.* Г.Тарханова

**УБЫРЛЫ́ КАРЧЫК** *и.* 1) *миф.* Урманда ялгыз яши торган коточкыч ямьсез, кеше ашаучы, эчендә убыры булган сихерче карчык. *Минутлар үткән саен, яктылык көчәйгәннән-көчәя барганлыктан, караңгылык, кара киемле убырлы карчык кебек, әкрен генә чигенә.* Г.Әпсәләмов. *Күп кенә тылсымлы әкиятләрдә геройның дошманы сыйфатында убырлы карчык персонажы очрый.* Л.Җамалетдинов

2) *күч.* Бик карт, ямьсез һәм усал карчыкларга карата әйтелә. *Син елга аръягында торган «убырлы карчык» белән танышмы?* В.Ильясов. *Нәрсә каркылдыйсың монда, убырлы карчык, котын аласың бит киленемнең.* К.Кара

**УБЫРЛЫ́ КОРТКА** *и. к.* **убырлы карчык**. *Фатыйма нәзек кыйгач кашларын җыерды, шомырт кара күзләрен кыса төште дә, ни әйтергә белмәүдән тәмам чарасыз калып, тулы ирennәрен бөрештереп бераз торгач: «Мәнсез карчык, убырлы кортка, ни сөйли тагын, ни булсын минем уемда?» – дип, ярсына-ярсына китеп барды.* М.Хәбибуллин

**УБЫ́Р ТАЯГЫ** *и. бот. к.* **шайтан таягы**

**УБЫ́Р УТЫ** I *и.* Органик матдәләр таркалганда хасил булган газларның караңгыда яктылык таратуыннан гыйбарәт сирәк табигать күренеше. *Шунда ул әлеге ут йомарламнарының убыр уты икәнен төшенеп алды.* М.Әмирханов. *Тубал чаклы булып, убыр уты Очып китте зират ягына.* Г.Афзал

**УБЫ́Р УТЫ** II *и. бот. к.* **шайтан таягы**

**УБЫРЫЛУ** *ф. диал.* 1) *к.* **убылу**. *Бер якта – башың әйләнердәй хәтәр, менә-менә убырылып-ишелеп төшәргә әзер текә яр.* А.Хәсәнов. *Сөйде күңел, сөйде янып, сөйде шашып, Упкыннарга убырылып, күккә ашып.* Р.Вәлиева

2) Берьюлы күпләп, тоташ агым булып бару, чыгу, керү һ.б.; ургылу. *Кара сөрем, аждаһа авызыннан убырылып--убырылып чыккан төсле, мин басып торган ноктага ташлана.* А.Гыйләҗев. *Бары тик, шартлаудан, йорт янындагы сирень куаклары таш, балчык белән убырылып күккә күтәрелгәч кенә, аңа игътибар иттеләр.* И.Сиражи

**Убырыла бару** Әзлекле рәвештә әкрен генә убырылу. *Әмма бөек дәүләт – Алтын Урданың ике гасыр дәвамында күрше руслар белән тотрыклы хезмәттәшлеге, һәлакәт чоңгылына убырыла барган илнең аяныч хәле, шул үткәндәге бергәлекне башка чорга күчереп карау иллюзиясен кузгалтасы калмаган.* М.Гайнетдин

**УВЕРТЮ́РА** *и. лат. махс.* 1) Опера, балет, кинофильм һ.б.ш.га музыкаль кереш. *«Бишташ» поэмасының керешеннән соң «Беренче таш» бүлеге (әнә шул без көткән симфониянең беренче бүлеге) увертюра булып яңгырый башлый.* М.Шабаев

2) Оркестр өчен язылган кечерәк күләмле музыкаль әсәр. *Увертюра яңгырый. Әйе, музыка – операның җаны, аның сихри канатларында ул югары күтәрелә, тыңлаучыларны үзенә ияртеп алып китә.* Г.Әпсәләмов. *Оркестр увертюра уйнап туктый.* Г.Зәйнашева

3) *күч.* Берәр эш-гамәл, вакыйганың башлангыч өлеше, төп вакыйгадан алдагы кереш өлеш. *«Язылмый калган җыр сагышы» да шагыйрь күңелендә йөргән зур әсәрнең увертюрасы булган.* М.Вәлиев

**УВУЛЯР** *с. лингв.* Телнең арткы өлеше кече телгә тию яки якынаю юлы белән ясала торган (аваз тур.). *Бары тик татар язуында увуляр [қ], [ғ] авазларын белдерү ихтыяҗы булганда гына, калын вариантта ялгана: хокукый, иҗтимагый, табигый һ.б.* Ф.Хисамова

**УГАЛАНУ** *ф.* 1) *кайт. юн. к.* **угалау** (*1 мәгъ.*). *Фриц, үзенең кемнәр кулына эләккәнен сизгәч тә, тәбегә баскан көзән шикелле, угаланырга, кычкырырга тотынды.* Г.Әпсәләмов

2) *күч.* Кемне яки нәрсәне дә булса көткәндә, нәрсә дә булса эшләр алдыннан чыдамсызлык күрсәтү, сабырсызлану. *– Абыйның кабер туфрагы да суынмаган, ә син мал дип угаланасың, – диде Йосыф, шелтәләп.* Н.Гыйматдинова

3) *күч.* Нинди дә булса күңелсезлек, уңышсызлык аркасында нишләргә белмәү, борчылу. *Угланнары язмышыннан угаланып, ачулана бөек кенәз үзен дә.* З.Мансуров

**Угалана башлау** Угаланырга тотыну. *Бер хәйлә табып: «Абау, эчем», – дип угалана башлады [ире].* К.Насыйри

**Угаланып алу** Бераз гына угалану. *Карчык, җайсыз утырган сыман, урынында кымшанып, ничектер угаланып алды.* Ә.Сафиуллин

**Угаланып тору** Күпмедер вакыт угалану. *Сабирҗан берара ишек төбендә угаланып торды.* М.Әмирханов

**Угаланып чыгу** Билгеле бер вакытның башыннан ахырына кадәр угалану. *Төне буе угаланып чыкты кыз, күзенә йокы әсәре кермәде.* Я.Зәнкиев

**УГАЛА́У** *ф.* 1) *кбт. форм. к.* **уу**. *Әхми пычрак җиңе белән канлы күзләрен угалады.* Г.Ибраһимов. *Сөмбел җирдә тәгәрәп яткан саргылт алманы, учында угалап, авызына капты.* Сөембикә

2) Нәрсәне дә булса кул белән төрле юнәлештә ышку, уу, массажлау. *Бу хәлдән куркып калган Исмәгыйль көчле куллары белән аны аягына бастырды, кулы белән аның чигәсен угалады, җиңелчә генә битләренә суккалады.* Ә.Сафиуллин. *Әһә, эш пешә болай булгач дип, кулларны угаладым.* И.Диндаров

3) Ике кул белән, бармаклар белән изгәләү, ваклау. *[Василий] папиросның берсен алып, ашыкмыйча гына ике бармагы белән угалап, авызына капты.* Ә.Еники. *Кабер янында бертын басып торды, иелеп, кичә генә казылган балчыкны алды, учында угалады.* М.Хәбибуллин

4) Уып арчу, чистарту яки йомшарту. *Равил ни әйтергә белми аптырап калды, кәгазьне кулында угалап-угалап торды да: – Дурак син, Костя, – диде.* Җ.Рәхимов. *Әмир, берничә башак алып, учында угалады, юк, умады, кылчыклары кулына кадалу белән үк, башаклар үзләре коелып төштеләр.* Х.Гыйләҗев

**Угалап алу** Тиз генә, аз гына угалау. *Нәби озынча яссы учларын угалап алды.* А.Гыйләҗев. *Тикшерүче ризыкка карап, кулларын угалап ала, мундиры өстенә салфетка куеп, тәмләп ашый башлый.* Г.Тарханова

**Угалап йөрү** Һәрвакыт угалау. *Кулы белән йөрәк турысын гел угалап йөри.* Р.Зарипов

**Угалап карау** Нәтиҗәсен белер өчен, сынау максаты белән угалау. *Баш агроном, учына туфрак алып, аны угалап карады.* Ә.Маликов. *Битен чәбәкләп, колакларын угалап карадым – аңына китерә алмадым.* Татарстан яшьләре

**Угалап кую** Аз гына, тиз генә угалау. *Гайфулла кулларын угалап куйды.* Ф.Яруллин. *Сүземне җөпләп, күземне дә угалап куйдым.* Р.Зәйдулла

**Угалап тору** Берникадәр вакыт дәвамында угалау. *Егет эчкәрәк узып урындыкка утырды һәм, сүзен нидән башларга белмәгәндәй, бераз тезләрен угалап торды.* Ә.Еники

**Угалый башлау** Угаларга тотыну. *– Сез чын мәгънәсендә подпольщиклар икән, – диде һәм кулларын угалый башлады.* Г.Әпсәләмов

**УГАТА** *рәв. диал.* Аеруча, бигрәк. *Анысы угата да яман кычкыра, колакларыңны куш куллап капла...* Ә.Баян. *Ай-һай-һай, балаңа килгәне угата авыр шул!* Н.Харисова. *Килен, синең кулың угата тәмле, коймак кына туглап ал әле.* А.Әхмәтгалиева

**УГЛАН** *и.* 1) *тар.* Сугышчы, яугир. *Дәүләттә хан, югары катлам руханилар һәм әмир-карачылар тәшкил иткән югары феодаль катламнан соң бәкләр, морзалар, угланнар, казаклар һәм буйсынучы халыкларның феодальләшүче югары катламнары торган.* Б.Хәмидуллин

2) *иск. к.* **олан**. *[Карчык:] Болай да бит күрәсез, угланнар, дерелдәп кенә торабыз.* Г.Исхакый. *Хуп, мин ата белән угланның бер-берсенә каршы яуга әзерләнә башлавы хакында әйттем инде.* В.Имамов

**УГЛЕВОД** *и. рус хим.* Үсемлек һәм хайваннар дөньясында киң таралган, углерод, кислород һәм водород кушылмасыннан гыйбарәт органик матдә. *Артык глюкоза югары молекуляр углевод – гликоген рәвешендә бавырда кала.* Органик химия

**УГЛЕВОДЛЫ** *с. хим.* Составында углевод булган. *Белгечләр әйтүенчә, углеводлы азык-төлектән тулысынча баш тартырга ярамый.* Кызыл таң

**УГЛЕВОДОРОД** *и. рус хим.* Молекуласы углерод һәм водород атомнарыннан гыйбарәт органик кушылма. *Табигатьтә чикле углеводородлар нефть һәм янучан табигый газлар составына керә.* Органик химия

**УГЛЕВОДОРОДЛЫ** *с. хим.* Составында углеводородлар булган; водородтан гыйбарәт булган. *Арзанлы углеводородлы чималны күпләп куллану чоры.* Н.Шәрифуллин

**УГЛЕКИСЛОТА** *и. хим.* Углерод диоксиды, углекислоталы газ. – *Шулай да бөркүрәк. Углекислота күбрәк ахры, көйләргә кирәк, – диде Фәрит.* А.Расих

**УГЛЕКИСЛОТАЛЫ** *с. хим.* Составында углерод диоксиды булган. *Углекислоталы тозлар*

**УГЛЕКИСЛОТАЛЫ́ ГАЗ** *и. хим.* Углерод белән кислород кушылмасыннан гыйбарәт иссез, төссез, һавада артык күп булганда буылуга китерә торган газ. *Яңа ягулыкның экологик өстенлеге дә исәпләп чыгарылган: аена 120 литр биоягулык файдаланып, автомобиль йөртүче атмосферага елына 250 килограмм углекислоталы газ чыгарылуын киметә.* Кызыл таң. *Шешә эченә аспирин салгач, ул, эрегәндә, углекислоталы газ чыгарып, бу сыеклыкны хәрәкәткә китерә.* Сабантуй

**УГЛЕКИ́СЛЫЙ ГАЗ** *и. хим. к.* **углекислоталы газ**. *Углекислый газ молекуласы бер углерод С атомыннан һәм ике кислород О атомыннан хасил булган.* Химия

**УГЛЕРОД** *и. рус хим.* Периодик системаның IV группасыннан С белән билгеләнгән, бөтен органик матдәләрнең составына кергән химик элемент. *Органик кушылмаларны өйрәнүне без бары тик ике генә химик элементтан – углерод һәм водородтан торган, гаять күп матдәләрне эченә алган углеводородлар классыннан башларбыз.* Органик химия

**УГЛЕРОДЛЫ** *с. хим.* Составында углерод булган. *Углеродлы корычтан эшләнгән гадәти аппаратлар ацетонитрил алу өчен кирәк булган кислоталы шартларда эшли башлагач, колонналарда серкә кислотасы барлыкка килә дә колонна стеналарын күгәртергә тотына.* М.Зарипов. *Углеродлы тимер эретмәләре кристаллашканда һәм кабатлана торган җылыту-суыту вакытында фаза әверелешләре кичерәләр.* Төзү материаллары

**УГОР** *и. төрки* Урал тел семьялыгының фин-угор тармагын тәшкил иткән маҗар (венгр), манси һәм ханты халыкларының гомуми этник исеме һәм шул халыкларның бер вәкиле. *Тик шулай да аң бул: заманалар үзгәрә, без сарматлар канаты астына кердек, син үзең белән угорлар кавеменең бер өлешен ияртеп алып кайттың.* М.Хәбибуллин

**УГОР-ФИН** *и. к.* **фин-угор**. *Гунтөрки халыкларының төрле төбәкләрдә таралып яшәве дә күптән билгеле, ләкин биредә күпчелекне барыбер угорфин, төрки халыклары тәшкил иткән булса кирәк.* М.Хәбибуллин. *Дөрес, болгарларга хас материаль культураның кайбер элементларын күршедәге угор-фин халыкларында да очратырга мөмкин.* Г.Таһирҗанов

**УГРА́У** *ф. иск. кит.* Дучар булу, очрау, грифтар булу. *Ахыр барчасы бердән, болар да минем кебек һәркайсы бер михнәткә ууграмыштыр, дип, башын түбән салып тордылар.* К.Насыйри. *Димәк, бүген-иртәгә безнең моңгарчы килгән мәктәп гадәтләремез, юлларымыз тәнкыйтькә, фәнни тәнкыйтькә уграячак.* Г.Исхакый

**УГРАШУ** *ф. иск. кит.* Эш итү, мәшгуль булу, маташу, көч-гайрәт сарыф итү. *Читтәге мөселманнарның хәле берлән уграшуны хәтерләренә дә китермәенчә, «Япониянe мөселман итәмез» дип йөртүчеләрдән, табигый, көләләр иде.* Г.Исхакый

**УГРО-ФИН** *и. к.* **фин-угор**. *Тикшеренүчеләр бу атаманы угро-фин телләренә дә, төрки телләргә дә нисбәтле дип карыйлар, ләкин ышандырырлык версияләр юк икәнен үзләре дә әйтеп үтәләр.* И.Хуҗин

**УГРЫ** *и. иск. к.* **карак**. *Эт, башын җиргә иеп, исни-исни кайчак бишалты километр уза һәм угрыларны чабуларыннан эләктерә.* Г.Кутуй. *Сез, угрылар, кызымның башын ашарга ябыштыгыз түгелме?* А.Гыйләҗев

**УГРЫЛА́У** *ф. иск. к.* **урлау**. *Мин ул угрыны беләм, ул узган ел Койтымбикә әбинең өч казын угрылады.* А.Гадел. *Явыз адәмнәр угрылап киткәндер, дигән шигебез бар, сездән, тәкъсир, шул хакта китап ачуыгызны түбәнчелек белән сорамакчы идек.* Ә.Еники

**УГРЫЛЫК** *и. иск.* 1) Урлау гадәте, угры булу. *Угрылыгыңны бар авыл беләчәк.* Ф.Яруллин. *Бер яктан, елан кабыгын салган сыман, Талбай да, угрылык гадәтен ташлап, намуслы адәм рәтенә чыкты.* З.Мурсиев

2) Кеше милкен яшерен рәвештә үзләштерү гамәле; караклык. *Угрылык белән көн итү кешене еллап кына түгел, сәгатьләп картайта икән ул, олан!* В.Нуруллин. *Угрылык өстендә тотылгандай булды, ахрысы, чибәр кызый тиен сыман сикереп юкка чыкты.* В.Имамов

**УГРЫНА** *бәйл. иск. кит.* Юлына; хакына; өчен. *«Дөньяны оҗмах ясыймыз» хыялы угрына аерым милләтләрнең бөтен хокукларын бетерү, аларның тупраклы мохтариятләрен гаскәр көче белән вату, аларның бөтен милли-мәдәни мөәссәсәләрен Николайга рәхмәт әйттерер дәрәҗәдә җимерү, бетерү, аларны үзләре теләгәнчә яшәү хокукыннан мәхрүм итте.* Г.Исхакый

**УГРЫНДА** *бәйл. иск. кит.* Юлында; өчен. *Моның угрында шәхси дошманлыклар, сыйнфый мәнфәгатьләр – һәммәсе дә онытылырга тиеш иде.* Г.Исхакый. *Көрәш угрында ар, тал, тирлә, имгән.* Г.Тукай

**УГЫЗ** I *и.* 1) *к.* **уыз**. *Ипиемне дә угыз белән изгән идем...* А.Гыйләҗев. *Сыер бозаулаганнан соң берәр атна*

*үтеп, угызы аерылып беткән, чиста, күбекләнеп, пары чыгып торган сөтне савып алып кергәннән соң башланган техник процесс турында сөйләмәкче булам.* А.Гыйльми

2) *окказ.* Сары шәфәкъ яктысы. *Июльдә генә була торган төннең караңгылы-яктылы угызында нәрсәдер яларып җирдән күккә күтәрелгән куллар, шәрә бармаклар чытырманын хәтерләткән урман авызына килеп кергәч, кайдадыр эчтәрәк гөрселдәп агач ауды.* А.Хәлим

**УГЫЗ** II *и.* Хәзерге төрек, азәрбайҗан, төрекмән, гагауз һ.б.ш.ның асылын тәшкил иткән, XI гасырга кадәр Үзәк Азия һәм Монголия территорияләрендә яшәп, соңрак көнбатышка таба күченгән күпсанлы төрки кабиләләр берләшмәсе һәм шуның бер кешесе. *Бүгенге көндә дә төркиләр нигездә ике төркемгә – кыпчак телләренә һәм угыз телләренә бүленәләр.* Н.Фәттах. *Юк, болар Ибраһимга электән үк таныш бәҗәнәкләр дә, кыпчаклар, аймыклар, угызлар да түгел.* В.Имамов

**УГЫЗЛАШУ** *ф.* Угызга әверелү, угыз булып китү; угыз телен, мәдәниятен үзенеке итеп таный башлау

**Угызлаша бару** Торган саен күбрәк угызлашу

**Угызлаша башлау** Угызлашу билгеләре белену. *Безгә ирешкән мәгълүматлар буенча, кашкайлар төбендә кыпчак теле, ләкин күрше угыз кабиләләре тәэсирендә угызлаша башлаганнар.* Р.Әхмәтьянов

**Угызлашып бетү** Тәмам угызлашу, тулысынча угызга әверелү

**УГЫЗЛЫ** *с. к.* **уызлы**. *Угызлы сөт белән сыйларсың картларны (малкай)!* Р.Бәшәр. *Өйгә, угызлы сөт күтәреп, Заһидә килеп керде.* Р.Сибат

**УГЫ́ЗЧА** *рәв.* **1.** 1) Угыз телендә. *Угызча сөйләшү*

2) Угызлар кебек, шулар гадәтенчә. *«Кыйссаи Йосыф» телендә угыз эпосыннан («Китаби Дәдәм Коркыт») алынган фразеологизмнар, метафоралар һәм теленең фонетик-морфологик үзенчәлеге шагыйрь Кол Галинең органик рәвештә угызча фикерләвен күрсәтә.* Н.Хисамов

**2.** *с. мәгъ.* Угыз телендә булган. *1900 елда Казанда басылган «Кыйссаи ике былбыл» китабында түбәндәге архаик формаларны һәм саф угызча элементларны күрәбез.* Ә.Нәҗип. *XX гасыр башларына хәтле угызча (көньяк төрки телләргә, аеруча төрек теленә хас) яңгыраш нигезендә язу ныклы традициягә кергән булган.* Р.Абдуллина

**УГЫЛ** *и. иск. к.* **ул** I. *Хәдичә ике угыл һәм дүрт кыз бала таба.* А.Тимергалин. *Без бит синең кем углы икәнлегеңне дә, ничек үскәнеңне дә күреп-белеп тордык.* А.Нәҗми

**УГЫР** *и.* Баштан Үзәк Азиядә яшәгән, бик иртә гомумтөрки бергәлектән аерылып Европага күчкән борынгы төрки кабиләләрнең бер өлеше; шул кабиләләрнең бер вәкиле; *русчасы:* **огур**. *Мәсәлән, III–IV гасырларда һун һәм угыр кабиләләре шулай берләшәләр.* Р.Әхмәтьянов

**УГЫРЛА́У** *ф. иск. к.* **угрылау**. *Һәркем гакыйль вә балигъ булып, ун дирһәм яисә бер алтын тәңкә акча угырласа, уң кулын беләгеннән кисмәк кирәк.* К.Насыйри

**УГЫРЛАШУ** *ф. иск. к.* **урлашу**. *Аның күгендә заһир булган бу кара болыт һаман зурая-зурая барып, ниһаять, Тимринең угырлаша башлавы ачык сөйләнә, шуның артыннан барып, мәсьәлә аның «указын алырга» тирәсенә җитә.* Г.Ибраһимов

**УГЫЧ** *и.* 1) Ашамлыкларны уып нечкә генә телемнәр яки порошок хәленә китерү өчен кулланыла торган үткен тырнаклы калай рәвешендәге кухня кирәк-ярагы. *Бәрәңгене ваграк турыйсың, тагы да куерак булсын өчен, угычтан да бераз уздырасың.* М.Мәһдиев. *Сарымсакны бик әйбәтләп угычтан чыгарам.* Э.Шәрифуллина

2) *а.х.* Ашлык бөртеген кибәктән, кылчыктан, кабыктан арындыру механизмы; *русчасы:* **шасталка**. *Археологик казу эшләре вакытында табылган таш китмәннәр, бөртек угычлар, эт һәм кәҗә сөякләре шул турыда сөйлиләр.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

**УДАР** I *и. рус* 1) *иск.* Бик көчле һөҗүм, кинәт булган хәлиткеч атака. *Дошманга бик күп ударлар ясыйбыз, әмма ул әле җиңелмәгән.* Г.Кутуй. *Алар тиз арада бер урыннан икенче урынга күчә, шулай итеп, дошманга көтмәгәндә удар ясый алалар...* В.Нуруллин

2) *күч.* Кемгә дә булса аяктан егарлык, бик начар тәэсир ясый торган авыр хәл, гамәл, вакыйга. *Ләкин үз гаризасының министр кулына эләгеп кире кагылуы... монысы аның өчен бик җитди һәм булып үткән хәлләрдән соң иң каты удар иде.* Г.Әпсәләмов. *Без шахтёрлар өчен шахталар ябылу каты удар булды.* З.Хәким

3) *сөйл.* Мигә кан саву, паралич, фалиҗ. *«Инсульт юк, инфаркт булмаган, мәгәр организмы нык таушалган, тегесенең дә, бусының да булу ихтималы бик мөмкин», – дип, Нәҗипне йөрәкләре удар алганнар палатасына салдылар.* А.Гыйләҗев

**УДАР** II *с.* **1.** 1) Хезмәттә планнарны һәм нормаларны үтәүдә алдынгы. *Ул менә, эшлик, ди, тырыша, башкаларга да тырышып эшләргә куша, ярышырга да каршы түгел, әмма аңар удар бригадалар төземәсеннәр, Борисны ударник итмәсеннәр, чөнки болар, аныңча, бар да формаль кебек күренә.* А.Алиш. *Төп удар төркем әйләнгеч юллар белән алдан җибәрелгән иде.* Ф.Зариф

2) Үтә әһәмиятле, кичектерелми торган, ашыгыч (эш, йөкләмә һ.б.ш. тур.). *Аннары удар төзелешкә килүчеләр заманча, шәп йортларга күченәчәк.* В.Имамов. *Бер төркем артистлар белән ул вакыттагы Ленинградка – удар комсомол төзелешенә культуралы хезмәт күрсәтергә бардык.* А.Хәмзин

3) Аеруча киеренке барган, интенсив (хезмәт тур.)

4) Шундый бик киеренке эшкә багышланган. *Удар бишкөнлек игълан иттеләр!* А.Гыйләҗев. *Вагонга җыелышкач, удар айлыкта җиңеп чыкканнары өчен, бригадага күчмә вымпел тапшырды.* Р.Вәлиев

**2.** *рәв. мәгъ.* Ударникларча; алдынгы ысуллар, темплар белән. *Эшче станокта удар эшли.* Һ.Такташ. *Актив эш алып барабыз Тавыклар арасында; Удар йомырка салалар Агы да, карасы да.* Г.Афзал

**УДА́РНИК** I *и. рус* 1) СССРда норманы, планны арттырып үтәүче алдынгы эшче. *Алай дисәң, фәкать безнең ристан гына Ударниклар исәбеннән төшеп калды.* М.Саттаров. *Түбән Кама сусаклагычы төзелә башлагач, су басасы җирләрдәге урманны кисү эшләрен производство алдынгысы, КПСС әгъзасы, Коммунистик хезмәт ударнигы Габбас Чанышевка йөкләделәр.* А.Хәсәнов

2) *сөйл.* Мәктәптә 4 һәм 5 билгеләренә генә укучы. *Минем энем ударник, ди. Гел бишле билгесенә генә укый, ди.* В.Юныс. *Яхъя белән миңа, училищены ударник булып тәмамлаганыбыз өчен, алга таба вузда укырга рөхсәт бирелде.* Г.Ахунов

**УДА́РНИК** II *и. рус* 1) *тех.* Утлы коралларда аткан вакытта патронның капсюлен бәреп вату өчен хезмәт итә торган деталь. *Кул астындагы иң җайлы материал агач булганга, тоттык та беренче наганны агачтан ясадык. Тоткасы да бар, көпшәсе дә – бары агачтан, резин белән худланган ударнигы гына тимер, ә күрер күзгә чын наганнан бер дә ким түгел.* А.Гыйләҗев

2) Уен коралларының бәреп тавыш чыгара торган өлеше

3) Ансамбльдә бәрмә уен кораллары һәм шуларда уйнаучы артист

**УДА́РНИКЛЫК** *и.* 1) Ударник булу сыйфаты. *Әгәр без баш тартсак, шулмы безнең ударниклыгыбыз?* А.Алиш. *Аннан соң үзегез узган собраниедә, ударниклык – эш сәгатен артык эшләүдә түгел, билгеләнгән сәгатьләрдә ялкауланмыйча җитез эшләүдә, дигән идегез.* Т.Гыйззәт

2) Тизләтелгән темплар белән башкарыла торган удар эш. *Кулакларның янавына карамастан, мин ударниклыкка язылдым.* К.Нәҗипова

**УДАРЧЫ** *и. к.* **ударник** I. *Урак күтәреп, чабаталар киеп, калхуз ударчысы булып йөри идем иң алдан эшкә...* Сөембикә

**УДАРЧЫЛЫК** *и. сир. к.* **ударниклык** (*2 мәгъ.*). *Имеш, ударчылык турында мең тапкыр чәйнәлгән бер балык башы бүген тагын мең дә беренче кат чәйнәлә.* А.Алиш. *Монда Гражданнар сугышы вакыты, эшчеләрнең завод өчен көрәшләре, корткычларның заводны ябарга маташулары, эшчеләрнең моны ачуы, ударчылык хәрәкәте, социализм ярышы һ.б. кергән.* Т.Гыйззәт

**УДЕЛ** *и. рус тар.* 1) XII – XVI гасырларда Русьта аерым кенәзнең биләмәсе булган территория, җир. *Ләкин Мәскәү Казанга гына түгел, Кырымга да, Әстерханга да, хәтта исеме белән ханлык (русча – «патшалык») булып саналса да, чынында Рус дәүләтенең удел кенәзлеге булган Касыймга да йөлым түләп килгән.* Р.Фәхретдинов

2) 1917 елга кадәр патша гаиләсенеке булган җирләр, күчемсез милек (1863 елга кадәр – крестьяннар да). *Әйләнә-тирәдәге иксез-чиксез алпавыт җирләренә, очсыз-кырыйсыз казна, удел урманнарына карап торырлык булгач, крестьян булып яшәвеңдә ни файда?* Т.Гыйззәт

**УДМУРТ** *и.* Фин-угор халыкларының Идел буе группасыннан Удмуртия Республикасында яшәүче төп халык (элекке атамасы: *ар*) һәм шул халыкның бер кешесе. *Татары, башкорты, русы, керәшене, марие, удмурты, чувашы – һәммәсе аңа киләләр.* Г.Әпсәләмов. *Әйләнә-тирәсендә удмуртлар, керәшен татарлары, берничә чакрым узып, чикне ашсаң – марилар.* М.Мәһдиев

**УДМУ́РТЧА** *рәв.* **1.** 1) Удмурт телендә. *Үзләре удмуртча пупалыймы, юкмы, мәгәр, сөйләшкәндә, синең чын татарыңны да сатып җибәрә ала.* В.Имамов. *Иң элек «рәхмәт» сүзенең удмуртча ничек булуын белештем: «тау» икән.* М.Хуҗин

2) Удмуртлар кебек, шулар гадәтенчә. *Сөйләшергә генә түгел, удмуртча биергә һәм җырларга да өйрәтеп маташтылар әле үземне.* Безнең гәҗит

**2.** *с. мәгъ.* Удмурт телендә булган. *Ләкин районга удмуртча китаплар бөтенләй диярлек килми.* Н.Фәттах

**3.** *и. мәгъ.* Удмурт теле. *Яшьрәк чагында ул бер ай Ар-Уразыда эшләгән, шунда беркадәр удмуртчага өйрәнгән.* Н.Фәттах

**УДЫРТУ** *ф. йөкл. юн. к.* **удыру**

**УДЫРУ** *ф. йөкл. юн. к.* **уу**. *[Мәмдүдә:] Аркамның сызлавына чыдый алмыйм. [Мәрьям:] Аркаңны удырасыңмы соң? [Мәмдүдә:] Юк.* Д.Салихов

**УДЭГЕ** *и.* Тунгус-маньчжур телләренең берсендә сөйләшкән, Россиянең Приморье һәм Хабаровск крайларында яшәгән төп халык һәм шул халыкның аерым бер кешесе. *Беренчесенә эвенк, эвен (ламут), негидаль, манегир (хумари), бирар (килер), солон, икенчесенә нанай (гольд), орок (Сахалин), ороч (Амур), удэге (удей), ульч телләре керә.* Ф.Сафиуллина. *Удэге тирмәсе*

**УДЭГЕ́ЧА** *рәв.* **1.** 1) Удэге телендә. *Удэгеча сөйләшү*

2) Удэгелар кебек, шулар гадәтенчә. *Удэгеча киенү*

**2.** *с. мәгъ.* Удэге телендә булган. *Удэгеча радиотапшыру*

**3.** *и. мәгъ.* Удэге теле. *Удэгечаны өйрәнә башлау*

**УЕЛ** *и. иск.* Киң уйсулык, иңкүлек

**УЕЛДЫК** *и.* Тигез өслектә уелып, эчкә батып торган урын. *Алар да, су читендәге ак таш катламын кәйләләр белән чокып, штольнялар ачып караганнар. --- Текә ярдагы карлыгач оясыдай уелдыклар шуннан калган.* М.Рафиков. *Елга буендагы уелдыкларда калган кечкенә-кечкенә күлләр камышларының дәртле алкышыннан сәламнәрнең кемнәрдән һәм кайлардан икәнен тоям.* М.Гәрәев

**УЕЛМА** *и.* **1.** Уелып алынган урын, уелдык. *Изаел кызга ишекнең читендәрәк булган уелмадагы ялтыравык тимерне күрсәтә.* Р.Гаязетдин. *Камераның өске өлешендә тәрәзә сыман тар гына уелма бар.* Л.Бадыйкшан

**2.** *с. мәгъ. к.* **уелмалы**. *Бу бинага керә торган ишек төньякта, аның түбәсе ярым овал рәвешендә, ишекнең тирә-яклары П рәвешле уелма бизәкләр белән бизәлгән.* Ф.Вәлиев

**УЕЛМАЛЫ** *с.* Уеп-уеп алынган, уелган; киртләч-киртләч. *Аның кояшта янган кып-кызыл бит урталары, бөтерелеп-бөтерелеп аккан Җаек суының уелмалы урыннары кебек, уйдык кына чокырланып торалар иде.* Н.Яһудин

**УЕЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **ую**. *Егетнең йөз чалымнары көнчыгыш кешесенә тартым иде: күзләре кысыграк уелган, яңаклары чыгынкы.* М.Маликова. *Себерләрдә уелдымы икән Әниемнең маңгай сырлары?..* Р.Вәлиев

2) Берәр өслектә эз калу, җәрәхәт барлыкка килү, нәрсәдер ярылу. *«Чыршы»да коктейль эчтеләр, Черек күлнең ышыграк урынына кереп, ireннәре уелганчы үбештеләр...* Г.Мөхәммәтшин. *Сез дә, яза-яза тиресе уелган нәзек бармаклар, төннәр буе сызламассыз.* Н.Гыйматдинова

3) *күч.* *Күңел, йөрәк, хәтер* сүзләре янында: онытылмаслык булып истә калу. *Бер-бер артлы тезелешкән ике, җиде, биш саннары хәзер инде мәңгелеккә йөрәгемә уелды.* Н.Гыйматдинова. *Ни өчен әнә шундый бер дә җуелмастай истәлек булып хәтергә уела алар?* М.Вәли-Барҗылы

**Уела бару** Эзлекле рәвештә һәрберсе уелу; торган саен ныграк уелу. *Әмма Хәйдәрнең һәр сүзе, яшен язмасы булып, Ләйләнең бәгыренә уела барды, ул күренешләр мәңгелеккә хәтеренә сеңеп калды...* Ф.Бәйрәмова

**Уела башлау** Уелырга тотыну. *Билен югалткан, көньяк хатын-кызларына хас булганча, авыз читендә сырлар уела башлаган Зара янында Рәшидә һич тә өлкәнрәк булып күренми иде.* М.Маликова

**Уела төшү** Бераз уелу; тагын уелу. *Язучының йөзендәге җыерчыклар, чәнечкеле тимерчыбык сыман, тирәнрәк уела төшә, ул бөтен гәүдәсе белән, кемнедер әче жилдән ышыкларга теләгәндәй, алга таба талпынып куя.* М.Вәлиев

**Уела язу** Чак кына уелмый калу. *Егет маңгаен уды. Кызарып, тиресе уела язды.* Н.Гыйматдинова

**Уелып бетү** Тәмам уелу. *Каз каурыйларын, йонын тарта-тарта, Моратның кул бармаклары уелып беттеләр, арыдылар.* З.Зәйнуллин

**Уелып калу** Ниндидер тәэсирдән соң уелган хәлгә килү. *Бу күренеш Нурзифаның хәтеренә, талантлы рәссамның картинасы кебек, бөтен төсмерләре, хәтта тавыш аһәңнәре белән уңмас-жуелмас булып уелып калды.* М.Маликова

**Уелып китү** Кинәт уелу

**УЕЛЫШ** *и.* Уелу рәвеше, уемның формасы. *Күз уелышы*

**УЕМ** *и.* 1) Чокып, уеп алынган урын; ырмау. *Ярыклар инъекцияләү билгеле бер тәртиптә алып барыла: ярык буйлап дисклы кайрак белән уем ясала һәм һава өрдерелә; ярыкка тишекләр тишелә һәм җилем кертү өчен ниппель урнаштырыла; ярыклар полимербетон яки гипс тутырып томалана.* Төзү материаллары

2) Кечкенә чокыр, батынкылык, чокырчык. *Аның кара күзләрендә очкын кабынгандай булды, шома бит очлары алланды, ирен читләрендә елмаю балкыды, кыенсыну аша сөенү йөзендә, хәтта тылсымлы ияк уемында да чагылды кебек.* М.Маликова

3) Уеп ясалган ашалый тишек. *Ишекне ябуга, Исрафил абый ачкыч уемыннан зал эчендәге реакцияне күзәтә.* Г.Гәрәева

4) Сын, ваза, йорт җиһазларын кую өчен, стенада уеп ясалган батынкылык; *русчасы:* **ниша**. *Караватстенадагы уем эчендә.* И.Салахов

5) Ишек яки тәрәзә өчен калдырылган яки кисеп алынган зур ашалый тишек. *Киндер чаршауны як-якка аерып, ишек уемыннан килеп чыккан озынча йөзле, малай гына дип әйтерлек кара коңгырт чәчле яшүсмер, кунакны күреп алуга, күңелле җанланып каршысына атлады һәм, кулларын сузып, оялчан гына күреште.* Рөст.Вәлиев. *Шулай дип үземне үзем дәртләндерә-дәртләндерә бераз тын алам да аннары, өй басучы караклар сыман, бөтен гәүдәм белән тәрәзә уемына керәм һәм җиргә аяк басам.* М.Вәли-Барҗылы

6) Махсус өлгедә кисеп, уеп алынган урын (киемдә). *Рахмай тагын нидер әйтмәкче иде, киенгәндә майкасының бер як җиң уемына башын да, кулын да тыккан булып чыгып, бу минутта ни башын, ни кулын чыгара алмый азаплана иде.* В.Нуриев

7) Җир өстендә казылган, чокылган, ашалган урын; чокыр. *Тик алар тауның теге ягыннан өскә таба күтәреләләр, анда баз кебек тирән-тирән уемнар бар.* Р.Муллануровa

**УЕМЛА́У** *ф.* Уем ясау, уем ую; уеп алу. *Җыю барышында чирәпләр берберсенең читен каплап салына, һәм шуңа күрә яссы чирәпнең файдалы мәйданы 50%, уемлап штампланган һәм тасмалы чирәпнең – 75–85% тәшкил итә.* Төзү материаллары

**Уемлап кую** Тиз арада уемлау; алдан ук уемлау

**Уемлый башлау** Уемларга тотыну

**УЕМЛЫ** *с.* Билгеле уемы я уемнары булган. *Хатынның битен ялкын теле ялмап алгандай булды: рәсемнән аңа күзләрен зур ачып, уемлы ияге белән үртәп, Әнисә текәлеп карап тора иде.* М.Маликова

**УЕМТЫК** *и.* Кечкенә генә яки сай гына уем. *Аннары, өстәп: «Без исән чакта бу каберлектә чәчәкләр шиңәргә тиеш түгел», – дип, кесәсеннән чәчәк орлыклары алып, таяк белән уемтыклар ясап, җиргә сибеп чыкты.* Р.Сәгъди. *Әллә дәрманым беткән, әллә болай тиз генә торасы итмәдем, озак кына яткач, урам ташының уемтыгында җыелып торган суга күзем төште.* Р.Зәйдулла

**УЕН** *и.* **1.** 1) Күңел ачу, ял итү, вакыт үткәрү өчен булган шөгыль; *киресе:* **эш**. *Ник дисәң, бүген ул иртәнге уен вакытында ботак очына кунган бер олы карганы тәү атуда бәреп төшерде.* М.Әмирханов. *Кояш офыкка якынлашканда, югары оч малайлары Әхмәтләр капка төбенә кичке уенга җыелды.* А.Гыймадиев

2) Күңел ачып вакыт үткәрү өчен билгеле кагыйдәләре, шартлары, катнашучылары булган шөгыль төре. *Картада ул зурдан кубып, бөтен җаны-тәне белән бирелеп уйный һәм уен кагыйдәләрен тиешенчә үтәүне намус эше дип саный иде.* М.Галәү

3) Шундый уеннарның командалар катнашында үткәрелгәннәрендә шул командаларның бер очрашуы, матч. *Кыш буе ул бер генә хоккей уенын да калдырмый, мөкиббән китә инде, шуңа чаба.* Р.Сәгъди

4) Шундый шөгыль төренең берәрсен уйнар өчен кирәк-ярак предметлар наборы, җыелмасы. *Шәһәрчектә шахмат-шашка ише өстәл уеннары, телевизор, футбол һәм волейбол туплары бар барын, китаплар да җитәрлек.* Җ.Рәхимов

5) Нинди дә булса коралда музыкаль әсәр башкару эше. *«Музыкаль оформление»нең бурычы – Җәмилә апа каткат колагыма киртләгәнчә, гармун уены аша «Яңа тормыш» колхозының күркәм омтылышын район җитәкчелегенә җиткерү, данын бөтен тирәякка тарату.* Р.Әмирхан

6) Нинди дә булса сәхнә әсәрен тамашачыга күрсәтү; спектакль. *Сәхнәдә уен вакытында Фатыйма Ильскаяның эчке итәге төшә башлый.* Р.Батулла. *Атаклы артист Ситдыйк Айдаров бик тапкыр, җор артист иде. --- Мәнә бервакыт уен барышында, стаканнан су эчәм дип стаканны авызына китергән иде, ясалма борын стакан кырыена ябышты да калды.* Ә.Яһүдин

7) Сәхнәдә нинди дә булса роль башкару. *Хезмәттәшләре турында җылы итеп сөйли: Дания Нуруллина, Фирдәвес Хәйруллина, Рузия Мотыйгуллина, Алсу Гайнуллиналар уенына соклана, бу артисткаларның олы рольләрдә зур образлар ачуына өметләнә.* Р.Юсупова

8) Карта уйнаганда иң зур саналган һәм теләсә кайсы картаны баса, яба ала торган карта төре. *«Тормыш кәрт уены кебек, иң читен чакта уен тузы коткара», – дип тынычландырырга тырышты ул үзен.* Ә.Баян

9) Шаяртып, уйнап әйтелгән, җитди булмаган шаян сүз. *Рәфис тә моны уенга алырга ашыкмады.* А.Вергазов. *Мин синең белән, олы башым белән, киләчәк тормышың, язмышың турында сүз алып барам. Гел уенга борып утырасың.* Т.Галиуллин

10) *күч.* Билгеле, гадәттә начар, максатка, яшерен нияткә корылган, алдан уйланып эшләнгән гамәлләр, адымнар һ.б.ш; интригалар, мәкерләр. *Шунда ук, бүләк өләшкәндәй, йөзенә ясалма елмаю чыгарды. Бусы – аппарат уеннарында оста түрәләрнең яраткан алымы иде.* Т.Галиуллин. *Иҗат кешеләре, кеше күңелен тирәнрәк аңлаучы буларак, сәяси уеннарга каршы чыгарга тырыша.* Р.Вәлиев // Билгеле кагыйдәләргә буйсыну; ясалма ситуация, ясалма кыланыш; шартлылык. *Габделнур бер тын дәшми торды. «Өзәргә кирәк араны, моңарда ышаныч юк, – дип уйлады. – Алга-артка карамыйча качарга*

*кирәк бу тирәдән». Шулай да уенны дәвам иттерәсе килде.* Р.Кәрами

11) *күч.* Билгеле бер һөнәр өчен типик ситуацияләр барлыкка китерү һәм шулардан гамәли чишелешләр табу, нәтиҗәләр чыгару. *Дамир дустымның әтисе, укытучы Нур абый, авыл яшьләренең хәрби уеннарын оештыручыларның берсе.* Л.Хәмидуллин. *Доклад та тыңладылар, рус теле түгәрәгенең эше, рус теле һәм әдәбияты кабинеты белән дә таныштылар, эшлекле уен уйнап алырга да өлгерделәр.* Н.Кәбәш

12) *күч.* Яктылык шәүләләре, төсләр, күләгәләр һ.б.ш.ның тиз-тиз алмашынуы, төрле төскә кереп уйнавы, җемелдәве. *Монда ул яраткан остазы Бродский, соңрак Р.Френц остаханәләрендә рәсем сәнгате серләрен өйрәнә, көннәрен төнгә ялгап, төсләр уенын, үлчәмнәр нисбәтен, сюжет, композиция кору осталыгын үзләштерә.* Т.Әйди. *Күпер булып, төсле нур уены Күккә әйдәп күздә калачак!* М.Нәзиров

**2.** *с. мәгъ.* Шаяртулы, уйнап әйтелгән яки уйнап эшләнгән. *Инде хәзер Разиядә баягы уен сүзләр юк, аның йөзенә җитдилек билгеләре чыккан иде.* А.Алиш. *Уен эшмени ул – кеше шатлыгын үтерү!* Ә.Еники

◊ **Уен гына** Бик җиңел, ансат кына эшләнә торган нәрсә. *Хәл бар, йөгереп кенә торам, көрәшүе – бер уен гына.* Д.Сабиров. **Уен түгел** *к.* **уен эш түгел**. *Назаның вакыты да аз: унынчы класс – уен түгел, ул керергә тиешле юрфакка егылып китәрлек конкурс була, ди, көздән үк тиешле тизлекне алмасаң, язын гына куып җитәрмен димә.* А.Гыйләҗев. **Уен эш түгел** Җитди нәрсә, шаяртырга, җиңел карарга ярамаган нәрсә. *Әйе, өйләнү – уен эш түгел. Гаилә – пулёмет расчеты кебек.* Р.Кәрами. **Уеннан уймак чыгу** Нинди дә булса эшнең, адымның яки уенның яхшылыкка китермәве, ахыры хәерле нәтиҗә бирмәү турында. *Уеннан уймак чыкмагае, дип куркуга калган Фәрит казлар арасына ташланды.* Р.Галиуллин. *Уеннан уймак чыкты бит, кызлар.* Ф.Яруллин

**УЕН-ҖЫР** *җый. и.* Уеннар һәм җырлар, күңел ачу. *Уен-җырлардан, уй-фикерләрдән аз гына бушанса да, әнә шул ике сүз кызның зиһенен биләп ала торган булды.* Р.Батулла

**УЕ́Н-КӨЛКЕ** *и.* Шау-шулы, җанлы, уенлы күңел ачу, көлеп-шаярып сөйләшүләр; мәрәкә. *Ләкин гаҗәп шат күңелле, уен-көлке ярата торган кеше, кызыл чыраеннан бервакытта да елмаю төшми, һәм юк кына кызыктан да балаларча рәхәтләнеп, корсагын селкетә-селкетә көлеп җибәрә иде.* Ә.Еники. *Габделнур, чыгарга кирәген дә онытып, уен-көлке белән шаяртып гәп коруын дәвам итте.* Р.Кәрами

**УЕН-КӨЛКЕЧЕЛ** *с. к.* **уенчак**. *Өске палубада җыелган команда членнары яр буенда озатып калучы туган-тумача белән кул, яулык болгап саубуллаша; бүген алар кичәге кебек уенкөлкечел, шаян түгел, барысы да уйчан, басынкы, йөзләре боек иде.* С.Сабиров. *Татар язучысы Фатих Хөсни дә, «Җәяүле кеше сукмагы» романында шул юл белән барып, уен-көлкечел, мәзәкчел, туктаусыз ил гизеп йөрүче крестьян егете Сәфәргалинең якты һәм онытылмас образын тудырды.* Р.Мостафин

**УЕНКЫ** *с.* Дугаланып торган, уеп алган кебек булган. *Һималай таулары. Тауның бер уенкы урыны. Таш өстендә, уйланып, барс утыра.* Х.Ибраһим

**УЕНЛЫ** *с.* 1) Хәрәкәтле уен белән бергә башкарыла торган. *Безнең авылның су буендагы уенлы җырлары, әнә шулай тормышның җанлы шаһитлары булып, сугышны тәмамладылар.* М.Мәһдиев. *Бу әсәр – музыкаль, җырлы, уенлы тамаша.* Р.Батулла

2) *сәнг.* Актёрлар уены белән бәйле булган. *Нагеш Кукунурның (Һиндстан) «Нить» фильмы сценарие «Ин яхшы уенлы кино сценарие», «Грбавица» фильмы режиссёры Ясмила Жбанич «Иң яхшы уенлы кино режиссёры» дип табылды, һәм, ниһаять, «Алтын мөнбәр» фестиваленең «Иң яхшы уенлы фильм» номинациясендә абсолют җиңүче итеп режиссёр Насер Хемирның «Баба Азиз» фильмы табылды.* Казан утлары

**УЕНЛЫК** *и.* Төрле күңел ачулар өчен билгеләнгән урын. *Шулай да кичен уенлыкка төшмәде.* Р.Батулла. *Су буенда, уенлыкта күрешербез.* Н.Кәримова

**УЕНЛЫ́-ЧЫНЛЫ** *рәв.* Бик үк җитди булмаган рәвештә; бөтенләй шаяртып та, бик үк чынлап та түгел. *Шулай итеп, ана белән ул уенлы-чынлы сөйләшкән булып, бик җитди мәсьәлә буенча бер-берсен бик яхшы аңлап, уртак фикергә килеп куйдылар.* З.Мурсиев. *Кайчакта кешенең тормышын бер уенлы-чынлы әйтелгән җөмлә, бер очрашу, бер кыю адым кискен үзгәртергә мөмкин.* К.Кара

**УЕНСЫЗ** *с.* **1.** 1) Уены булмаган, уеннан башка башкарылган. *Уенсыз туй бит ул кияүсез кыз кебек.* Н.Арсланов

2) Җитди, шаянлык, шуклык катнашмаган. *– Төштән бирле эзлим үзегезне, – дип, уенсыз сөйләүгә күчте ул аннары.* М.Хуҗин

3) *сәнг.* Актёрлар уены белән бәйле булмаган, уенлы түгел; документаль. *Уенсыз фильм*

4) Уенчы тарафыннан идарә ителми торган (компьютер уеннары персонажы тур.)

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Уеннан башка, уен уйнамыйча. *Шул гади сүзләрдән соң, арадан бер шаяны әйтә сала: «Кызларның сылулары, җегетләрнең асыллары каракаршы килгән икән, бер уенсыз үтеп китәргә ярамас...»* Г.Ибраһимов. *Тик уенсыз яшәү күңелсез...* Л.Шагыйрьҗан

2) Шаяртусыз, чынлап. *Кәрименең сүзе, үзенә калса, уенсыз әйтелгән булып чыкты.* К.Тимбикова

**УЕНТЫ** *и.* **1.** *к.* **уем**. *Аның борын янындагы уентысы буйлап яшь бөртеге тәгәрәп төште.* А.Вергазов. *Шулай шактый озак карап торганнан соң, йомшак кына итеп аның бөдрә чәчләреннән сыйпады, бармаклары белән матур гына батып торган ияк уентысын сыпыргалап куйды.*Г.Галиева

**2.** *с. мәгъ.* Уелып торган, чокыррак булган. *Далага якынрак тау итәкләре монда да әле шәп-шәрә иде, арырак, бигрәк тә тау араларында, уенты җирләрдә сирәк-сирәк куаклар, әрәмәләр күренгәли.* Н.Фәттах

**УЕНТЫК** *и. к.* **уемтык**. *Ана җофар тал каршындагы уентыкка килеп җиткәч кинәт чумды, аның кунакнык\u044bна охшаш озын койрыгы күренеп алды.* Р.Батулла. *Көне буе чалгы-сәнәк селтәүгә карамастан, яшь-җилкенчәк киң тугайның аулак бер уентыгында кичке уенга җыела торган иде.* В.Имамов

**УЕНТЫ́К-УЕНТЫК** *рәв.* **1.** Уентылар рәвешендә; киртләч-киртләч булып. *Юл шактый чыпырдаган, ара-тирә уентык-уентык булып күлдәвекләр җәйри.* А.Вергазов. *Сыза кипшергән, чит-читләренә котырынып үлән калыккан, уентык-уентык булып кузгалак тишелеп чыккан, таш чәчелгән җылы яр ярыкларыннан, шыштырдап, кәлтә еланнар йөгереп чыга.* А.Гыйләҗев

**2.** *с. мәгъ.* Уентылы, уентылары булган. *Ул вакытта әле монда урман аланы кебек уентык-уентык урыннар булган.* Ф.Гарипова. *Агач аягының*

*уентык-уентык эзләре буенча барып, әкиятчебезне тәки эзләп таба идек...* Г.Мөхәммәтшин

**УЕНТЫЛАНУ** *ф.* Уелу, чокырлану, эчкә батып керү. *Идарәнең икенче катына менә торган уентыланып ашала башлаган таш баскыч кырыйларына кайсы арзанлы материя белән тышланган кыска тун, кайберсе җылы сырма кигән, битләре ачык һавада эшләүдән янып коңгырт төскә кергән ир-атлар сырышкан.* А.Вергазов

**Уентылана төшү** Бераз гына уентылану; тагын уентылану

**Уентыланып тору** Уентыланган хәлдә булу

**УЕНЧАК** *с.* **1.** 1) Шат табигатьле, шаян, шук, мәзәкчел. *Аның шушылай шаяртып торуы миңа элекке заманнардагы ишек бавын сагалап торучы уенчак яшь кызларны искә төшерде.* М.Вәли-Барҗылы. *Ул шактый соң – утыздан узгач кына бер яшь студентканы алды һәм, өйләнгәч тә, элеккечә үк уенчак булып калды, ирекле, гамьсез яшәвен дәвам итте.* М.Маликова

2) Сикерергә, уйнакларга, чабып йөрергә яратучан. *Исхактан күз дә алмый торган биш-алты олырак малай, арада Хөсәен бар иде бугай, шәрә тән судан ыргылып чыктылар да, уенчак тайлар кебек кешнәшеп, аны куып җиттеләр, күз ачып йомганчы җиргә ектылар, тартып-йолкып, күлмәкыштанын салдырдылар.* А.Гыйләҗев. *Мин урынымнан сикереп торам да үзебезнең ак маңгайлы, гаҗәеп уенчак, гаҗәеп наян бозауны уйсулыкка алып төшәм.* Р.Фәизов

3) Җитди булмаган, шаян. *Сибгат Хәким иҗатында сатирик, юмористик, уенчак шигырьләрнең булмавы хисләрнең әнә шулай салмак-саллылыгыннан киләдер шикелле тоела миңа.* Г.Рәхим. *Халык инде сүлпәнләнә төшкән, артык кычкырып та сөйләшми, уенчак сүзләр дә кимегән иде.* А.Тимергалин

4) Шуклык, шаянлык белдергән, уйнап эшләнгән. *Майланып, елтырап торган киң кара йөзе, кош йомыркасыдай зур кара уенчак күзе, бер дә пәке тиерелмәгән зур чылгыйлы кара мыегы --- – моның рус гаскәренең алгы сафында Парижга барып кайткан мәшһүр тарихи каһарманнарның калдыгы икәнен ачык күрсәтәләр иде.* Г.Ибраһимов. *Буяган авыр керфекләрен күтәреп карады да: «Мине эштән чыгармакчы буласың икән», – диде, ничектер һәрвакыттагыча уенчак тавыш белән.* Х.Камалов

**2.** *рәв. мәгъ.* Җитдилек белән түгел, уйнап, шуклык белән. *Шәһәрдән килгән ирләргә яшь хатын күптәнге таныштай уенчак эндәшә.* Ш.Галиев. *Нәфисә уенчак елмайды.* Р.Зәйдулла

**УЕНЧАКЛЫК** *и.* Уенчак булу, шаянлык, шуклык. *Анда хәзер элекке яшьлек уенчаклыклары сүнгән иде.* Т.Гыйззәт. *Хәзер ул уенчаклыкны акыл һәм тәҗрибә буйсындырган.* Ә.Гаффар

**УЕНЧАН** *с.* **1.** Уен-көлке, мәзәк ярата торган; шаян, шук. *Мансуров, туташны ярым кочаклап, шат, уенчан көлке тавыш белән: – Разыя! Разыя иптәш! Сез мине буып үтерәсез, тын алырга бирегез! – диде.* Г.Ибраһимов. *Бу ике дөньяның күкләре, кояшлары бер-берсенә каршы тора, агачлары, ярлары, манаралары тискәре торалар. Боларның астагысы тагы да матуррак. Тагы да уенчанрак.* Ф.Вәлиев

**2.** *рәв. мәгъ.* Уйнаклап. *Менә скрипка кылларының беренче авазлары, болын күбәләкләредәй уенчан, җиңел бөтереләп, күңелләрне җилкендерә-җилкендерә, зал өстендә тирбәлә башлады.* Г.Бәширов

**УЕНЧЫ** *и.* 1) Нинди дә булса уенда катнашучы. *Кыз, тупны алып, уенчылар ягына ыргытты.* З.Мурсиев. *Ике уенчы эт булып өрә башлый.* Р.Батулла

2) Комарлы уеннар белән мавыккан кеше

3) Нинди дә булса музыка коралында уйнаучы. *Зөлхәбирә кулына кабал алды. Өй эченә сагышлы аһәң таралды. Аңа илаһи бизәк булып, уенчының бераз калтыраулы, әмма йөрәкне чеметтерердәй самими тавышы кушылды.* М.Әмирханов

**УЕНЧЫК** *и.* **1.** 1) Балаларга уйнар өчен ясалган әйбер. *Кызы, ашыгаашыга, ничек әлэкте шулай Айзизәнең уенчыкларын, үзенең киемнәрен көпчәкле зур чемоданга тутырып ята иде.* Т.Галиуллин. *Сәлим исә күбрәк агач уенчыклар, сыннар ясау белән мавыга.* Г.Гыйльманов

2) *күч.* Әһәмияте булмаган әйбер, күңел ача торган вак нәрсә. *Без әнә шул сәләтебезне культура дигән ялтыравык уенчыкка алмашканбыз һәм кояш чыкканны да бик сирәк күрәбез...* А.Тимергалин

3) *күч.* Башка кеше ихтыярына тулысынча буйсынып, аның мәнфәгатенә, ихтыяҗына хезмәт итә торган зат. *Хатын-кыз сезнең өчен я уенчык, я бер корал гына.* М.Кәбиров. *Хәер, монысы да – бик гади чишелә торган мәсьәлә, аңлашылып тора: кызга уенчык кирәк булган, бары шул гына! Йосыф – уенчык!* Ф.Яхин

4) *күч.* Мөстәкыйль рәвештә карар кабул итеп, үзе теләгәнчә эш итә алмаган, башкаларның кушуын үтәгән, башка берәүнең кулында сукыр корал булган кеше, дәүләт һ.б.ш.; марионетка. *Ак йортка президент булып килгән демократик партия җитәкчесе Джек Диксон, хәрбиләр ярдәменә таянып, АКШта диктатура урнаштырды, Конгрессны һәм аның курчагына әверелгән Берләшкән Милләтләр Оешмасын таркатты.* З.Мәхмүди

**2.** *с. мәгъ.* 1) Уйнар өчен эшләнгән. *Тартмадан идәнгә артсыз урындык биеклеге уенчык экскаватор килеп төште.* Җ.Рәхимов. *Кызларның чәчләрен тартып, кулларын каерып, аларны уенчык тычкан белән куркытып йөрүче шул малай инде.* Г.Гыйльманов

2) Бик кечкенә, чынга охшамаган. *Сары нарат такта белән пөхтә итеп тышланган бу җыйнак корылма уенчык йортны хәтерләтә иде.* Р.Низами

3) *күч.* Тулы канлы, мөстәкыйль, чын булмаган. --- *хөррият дигән нәрсәне җуеп, шәхесне җәмгыятьтә, коллективта (моны социализм дип атасак та була) харап итүебез һәм уенчык парламентларга, сайлау хокукларына төренгән әлеге дә баягы золымга кире кайтып, яңадан кадими тәртипләрне кабатлый башлавыбыз мөмкин.* А.Тимергалин

◊ **Уенчык кебек (шикелле, төсле)** Берәр кеше яки берәр нәрсәнең бик матур, нәфис, җыйнак булуы турында. *Ләкин берничә көннән соң әле заводтан күптән түгел генә чыккан һәм шалтыр-шолтыр трамвай белән чагыштырганда уенчык шикелле троллейбуста барганда, янә шулай кискәләнгән пәрдәгә игътибар иттем.* А.Тимергалин. *Икенче көнне Алсинә белән Өлфәт, көнбагыш чәчәгедәй сары, уенчык кебек кечкенә машиналарына утырып, Наратка, әнисенең риза-бәхиллеген алырга китеп бардылар.* Р.Габделхакова

**УЕНЧЫЛ** *с.* Шаян сүзле, мәзәкчән, уенчак. *[Саттар Әминәгә:] Мин сине котыртып кына әйттем, ни эшләр икән дидем, мин бит уенчыл кеше.* Ф.Сәйфи-Казанлы. *И-и, аларда да*

*явадыр әле бизәкле, уенчыл карлар, име, улым.* М.Хуҗин

**УЕНЫ́-ЧЫНЫ** *җый. и.* Шаярту катыш җитдилек, җитдилек катыш шаярту. *– Соң алып кайт, алай бик мәшәкать тансыкласаң, – диде Шаяз беркөнне, уенын-чынын бергә кушып.* Җ.Рәхимов. *Әллә шаяра, әллә уены-чыны бергәме?* Г.Галиева

**УҖАР** *и. диал.* Ярсу, котыру, усаллык

**УҖАРЛАНЫП** *рәв. диал.* Котырынып. *Күренде күк йөзендә кара болыт, Болганып гайрәт белән, уҗарланып.* Дәрдемәнд. *Уҗарланып арттан сулары йөрәкләрне, ай-яй, йончытты!* З.Мансуров

**УҖАРЛЫ** *с. диал.* Ярсу, котырынган, усал; үҗәт, кире

**УҖАРЛЫК** *и. диал.* Ярсулык, уҗар булу сыйфаты. *Уянмасын өчен уҗарлыгы, җирәндереп хәтта... җир өен, җырлашырга кала, җыйнаулашып, бәддогалы бишек җыруын.* З.Мансуров

**УҖА́У** *и. диал.* Аш чүмече. *Аның исәбе --- казанда үзенә бер-ике генә уҗау буш умач пешереп алу иде.* Ә.Еники. *Марат абыйдан соң ул да тагын бер уҗау аш өстәттереп алды.* Д.Булатова

**УҖЫМ** *и. рус* Көзен чәчелеп, шытып чыгып, кар астында кышлый торган берьеллык иген. *Җирне тиресләп яхшырткannan соң, әүвәл арыш уҗымы вә богдай уҗымы чәчәләр.* К.Насыйри. *Рәхәт, йомшак язгы күкрәүләре белән яшь уҗымнар өстенә ләйсән яңгыр да явып узгач, тагын тынычланган иде карт.* Г.Сабитов

◊ **Уҗым бозавы** Ихтыярсыз, бик юаш, үтә йомшак холыклы, җебегән, булдыксыз кеше. *Аның Хәбибрахманы бик юаш, бик ышанучан бит. Гел уҗым бозавы инде.* М.Мәһдиев. *Уҗым бозавы, сарык, аңгыра син, ахмак, Бохара диванасы! Акны карадан, кияүдән кайткан хатынны кызлардан аера белмәгән мәхлук...* Н.Әхмәдиев. **Уҗымга бару** *к.* **уҗымга чыгу**. *Сугышка кадәр авылда азгынрак ир-атлар уҗымга баргалый торган бер-ике генә хатын була --- иде.* Н.Әхмәдиев. **Уҗымга йөрү** *к.* **уҗымга чыгу**. *[Майшәкәр:] Башкалар ир белән яшәгәнгә ачуың киләмени, чепи күз! Уҗымга йөрмиләр ие аны, менә ирең дә ташлап китмәгән булыр иде.* Аманулла. **Уҗымга керү** *к.* **уҗымга чыгу**. *Иренең шул хәрәкәтеннән Лениза күп нәрсәләр искәрә: димәк, мине сагынган, миңа тугрылыклы булган, уҗымга кермәгән.* Х.Камалов. *Хатын-кыз тоемы белән җефетенең читтә чиртерү, уҗымга кергәләп чыгу ихтималы барын белсә дә, --- гаиләне сакларга --- тырышты.* Т.Галиуллин. **Уҗымга чыгу** Ир яки хатын гаиләдән читтә башкалар белән чуалу, якын мөнәсәбәттә, мәхәббәт бәйләнешендә булу. *Азмыни хатыны бала тудыру йортында ятканда уҗымга чыгып алучылар!* М.Мәһдиев. *Әхәт абый бит үтә чая, бик елгыр, күзе уйнап тора торган ир-егет булган. Кайчакларда уҗымга чыккалап керергә дә күп сорамаган.* Ә.Рәшит

**УҖЫ́М КҮБӘЛӘГЕ** *и. зоол.* Ябалакчыклар семьялыгыннан башы һәм күкрәгенең алгы ягы куе йонлы, тышкы күренеше белән ябалакка охшаш, уҗымга зыян сала торган күбәләк; *русчасы:* **совка озимая**. *Уҗым күбәләгенә каршы чаралар күрү*

**УҖЫ́М ЯБАЛАКБАШЫ** *и. зоол. к.* **уҗым күбәләге**

**УҖЫ́М ЯБАЛАКЧЫГЫ** *и. зоол. к.* **уҗым күбәләге**

**УЗАМАН** *и.* 1) Кулыннан һәр эш килерлек нык, булдыклы, көчле кеше. *Киткәндә малай озатсаң, ир-егет булып җиткән узаман каршыла.* И.Мөсәнниф. *Ничектер, тормышында мөһим эшләр башкарганнан соң һәм алдагы көннәрдә катлаулы вә авыр гамәлләргә тотынасы алдыннан тәвәккәллек җыю өчен, Солтанъяр атлы ир узаманы менә шушы тау башына менә икән.* З.Мурсиев

2) Оештыру сәләте югары булган, шул эштә абруй казанган, үзенә ияртүче кеше; лидер. *Теге – узаманнары иде ахрысы, чөнки һәр төркемнең бер башы була, калганнары – яраннар.* Х.Камалов. *Исхакый большевиклар узаманы Ленинның акылдан язуын, Сталинның ышанычсыз калуын, сәер үлемен, Гитлерның үз-үзенә кул салуын белеп үлә.* Т.Галиуллин

3) Уенда башлап йөрүче, уен башында торучы; уен кагыйдәләре нигезендә активрак вазифаларны үтәүче. *Бәләкәй чакта ук сугыш уеннарында гел узаман булып уйнарга яраткан Вакыйф бүген дә «атлар хәл алсын» дигән сүзен, каршы килеп тормаслык итеп, өзеп әйтте.* А.Гыйләҗев

**УЗАМАНЛЫК** *и.* Узаман булу; лидерлык. *Әминә апа үзе дә мөстәкыйль фикерле, үз сүзен өздереп әйтә торган узаманлык – лидерлык сыйфатларына ия кеше иде.* Т.Галиуллин. *Ул [Г.Ибраһимов] башка өлкәләрдә дә (әдәби тәнкыйть, тел белеме, тарих, җәмәгать эше һ.б.) беренче булырга омтылган. Ф.Миңнуллин, аңа узаманлык хас, дип әйтә.* Ф.Бәширов

**УЗА́-УЗЫШКА** *рәв.* Узуга; узып барган чагында. *Уза-узышка ук күптәнге таныштай гәпләшеп килә.* Ш.Галиев

**УЗГА́Н-БАРГАН** *с.* **1.** Кайдан да булса узып баручы, үтеп йөрүче (теләсә кем). *[Байбикә:] «Җыен узган-барган браматның аягын бастырасы булма, ризалыгым юк!..» – дип, бер җикеренде.* М.Хәсәнов. *Узган-барган кешеләр дә аларга килеп кушыла.* В.Имамов

**2.** *и. мәгъ.* Узгынчы, юлаучы, узып баручы кешеләр. *Нәрсә син, кордаш, узган-барганны туктатып сөйләшеп торасың.* Т.Гыйззәт. *Аек вакытта узган-барган белән исәнләшергә дә кыймаган кешенең тавышы ул көнне безнең урамдагы барлык морҗаларның корымын коя.* Р.Газиз

**УЗГЫНЧЫ** *с.* **1.** 1) Кая да булса узып баручы, юл йөрүче (кеше). *Шушы вагоннарның кайсындадыр Рөстәм өчен бик кирәк бер нәрсә калган кебек тоелды, һәм ул кинәт йөрәген җиде-сигез сәгать буена ашкындырган узгынчы кызның исемен дә, фамилиясен дә белмәвен исенә төшерде.* Һ.Такташ. *Алар да узгынчы кешеләргә өметле күзләр белән карыйлар.* Ф.Җамалетдинова

2) Узып китә торган, тиз уза торган, вакытлыча (авыру, яңгыр һ.б.ш. тур.). *Гомерлек чир түгел, узгынчы сырхауның да ни икәнен белмәгән яшь, таза чак бит.* Л.Ихсанова. *Бәргәләнеп йөри узгынчы җил, Кайсы чордан, кайсы илләндер ул?* Р.Миңнуллин

3) Вакытлы, очраклы. *Акыл галәм чиксезлегенә югарырак күтәрелгән саен, түбәндәге мөһимрәк һәм узгынчы күренешләр ачыла төшәр, яхшырак күренер.* Ш.Галиев. *Ул бүләк синең поэзия белән шөгыльләнүең, шигырь язуың узгынчы бер мавыгу гына түгеллеген исбатлый һәм синдә шагыйрь үсәсен күрә алган бу бичараның да күңелен күтәрә.* Ф.Яруллин

**2.** *и. мәгъ.* Узып баручы юлчы, юлаучы кеше. *Тик берзаман артына борылып карагач кына, Амантай хәвефләнә калды һәм, терсәге белән иптәшенә төртеп, узгынчыга баш изәп куйды.* Т.Әйди. *Кичәге маэмайлар да шул тирәдә чуала, сирәк-мирәк узгынчыларга өргәләп ала иде.* М.Маликова

**УЗДЫРТУ** *ф. йөкл. юн. к.* **уздыру**. *Яубаш Атилла, ыстан туктап торганда, бер генә сәүдәгәрне дә калага таба уздыртмады.* М.Хәбибуллин

**УЗДЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **узу**. *Күкрәк баласының үзенә генә хас баш әйләндергеч татлы исе күп хатирәләрне күз алдыннан уздырды.* Г.Галиева

2) Үткәреп җибәрү, узарга, үтәргә мөмкинлек бирү. *Юл ярып, сәетне түргә уздырдылар.* В.Имамов. *Күршеңне кухня һәм кунак бүлмәсеннән ары уздырма.* М.Мирза

3) Юл сабып, узып китәргә, алга чыгарга мөмкинлек бирү; башкаларны алга җибәреп, үзең артка калу. *Имеш, Прагунны чыккач узыша башлыйлар, тае һичберәүнең атын үзеннән алга уздырмый, хәтта Капать атлары уза алмый, җил кебек оча.* Г.Әпсәләмов. *Менә ул, учларын каш өстенә куйган килеш, сабыр гына Гайнанны көтеп алды да, аны уздырып җибәрергә теләгәндәй, читкә тайпылды...* Г.Гыйльманов

4) Вакытны, гомерне кайдадыр яки ничектер үткәрү. *Газинурның кызлары да аланда уздырган көннәрен, әтиләре янында шалашта кунган кичләрен үз тормышларындагы иң бәхетле минутлары итеп санайлар бугай.* А.Хәсәнов. *Ничек тә бу кышны хәвеф-хәтәрсез генә уздырасы иде.* Н.Гыйматдинова

5) Оештырып башкарып чыгу, үткәрү. *Бу көзне Кадын-көй кешеләре, туган ил гадәте буенча, яңа җирдә беренче тапкыр каз өмәсе уздырдылар.* М.Галәү. *Мәҗлес уздырырга сорамый бит, китап бастырырга...* Р.Фәйзуллин

6) Нәрсәдән дә булса чистарту, арындыру, билгеле үзлек бирү һ.б.ш. максат белән берәр нәрсә аша үткәрү. *Агымсу! --- Син аларны [кирәкмәс нәрсәләрне] ерак-еракларга алып китәсең, әллә нинди фильтрлар аша уздырасың, юасың, төбеңдәге төпкелләргә, чокыр-чакырларга тутырасың, үзүзеңне һаман шулай сафландырасың.* Г.Үзиле. *Көтүгә куганчы, сыерларын савалар, сөтне сепарат аша уздыралар, ипи салырга он илиләр, мичкә ягарга утын кертәләр.* М.Хәсәнов

7) *сөйл.* Нинди дә булса комиссиядән тикшертү, кемнән дә булса карату. *[Хуҗалык командасындагы] солдатларны, денщикларны, кучерларны һәм башкаларны яңадан комиссия аркылы уздырып, яраклыларны фронтка җибәрделәр.* М.Гали

8) *сөйл.* Тавыш бирү, сайлау, конкурс нәтиҗәсендә кая да булса үткәрү, сайлау, сайлануны раслау. *Налог инспекциясе төнге уникегә кадәр утыра. Ник? Фәкать минем кандидатураны кандидатлыктан төшереп калдыру өчен, депутатлыкка уздырмас өчен.* Н.Хәсәнов. *[Мөкатдимә (кул бирә):] Улыңны конкурстан уздырдым, Шәмсенур апа.* Ю.Әминов

9) *күч.* Башкалардан өстен чыгу, җиңү, беренчелекне алу. *Иван Айвазовский – корифей! Аны уздыру мөмкин түгел.* А.Хәсәнов. *Арба туктаусыз шыгырдады, тургайлар өзлексез сайрадылар, чикерткәләр бер-берсен уздырырга тырышып чырылдадылар...* А.Гыйләҗев

10) *күч.* Кайгы, авыру һ.б. кичерү, үткәреп җибәрү. *«Бөтен авырлыкларны, дөньяның хәсрәтләрен уздырдым инде, балаларның, оныкларның игелекләрен күреп яшәргә язсын», – дип уйлаган иде Нажия әби.* Р.Баттал

11) *күч.* Кайбер чыгыш килешендәге исемнәр янында: кичерү, үткәрү. – *Үткәннәрне баштан уздырганда, бик күп хәлләр искә төшә, – диде Хәбиров.* Б.Камалов

**Уздыра бару** Һәрберсен эзлекле рәвештә, рәттән уздыру. *Әмма Фәхри Хисами – хатынын югалткан, гомерен кысыр уздыра барган кеше.* Ф.Яхин

**Уздыра башлау** Уздырырга керешү. *Шуннан кире чыгып, кәрван кешеләрен берәмләп кенә чатыр эченә уздыра башлый.* Ә.Еники

**Уздыра төшү** Бераз гына уздыру; тагын уздыру. *Үзе яшьрәк тә, ул өченче көнге мәҗлеснең түрендә булып, моның нигъмәтен ашаган, шәэнен күргән, башкалардан да уздыра төшеп, һиммәте өчен тәхсин кыйлган иде.* Г.Ибраһимов

**Уздырып бару** Булган берсен бербер артлы уздыру. *Ул бу егетнең начар ниятта түгеллеген, аның чибәрлеген, мөлаемлеген үзенең уйлары, хисләре аша уздырып бара иде.* А.Нәҗми

**Уздырып җибәрү** Җиңел генә уздыру; көтмәгәндә уздыру. *Төскә-башка әтисенә охшаса да, җыр-моңга әнисе Диләрә ханымнан да уздырып җибәрә, диләр.* З.Мурсиев

**Уздырып йөрү** Озак вакыт дәвамында, күп итеп уздыру. *Йөзләгән кешенең башын әйләндереп, акчалы сеанслар уздырып йөри, мөртәт...* Д.Гыйсметдин

**Уздырып калу** Уздырырга өлгерү. *Әллә сәхнәдәге гомерләре кыска булганга тиз-тиз генә уздырып калырга ашыгалармы шунда!* Сөембикә

**Уздырып карау** Нәрсәнеңдер булу-булмавын, килеп чыгу-чыкмавын сынау максаты белән уздыру. *Бие, бие! Нәрсә карап торасың! Уздырып кара мине!* М.Маликова

**Уздырып кую** Тиз арада яки алдан уздыру. *Тиздән, булдыралган кадәр шартына китереп, туен да уздырып куйдылар.* З.Мурсиев

**Уздырып тору** Гел, даими уздыру. *Туктаусыз җыелышлар уздырып торудан, мактәпнең дә, укучыларның да рәте китте.* И.Салахов

**УЗДЫРЫЛУ** *ф. төш. юн. к.* **уздыру**. *Дөрес, баш урынына сары төстәге һәм чүлмәккә охшаган түгәрәк фигура ялтырый, ә «гәүдә» аркылы билбау сыман тасма уздырылган.* К.Гыйззәтов. *Икенче көнне Зарифлар өендә бик күркәм Коръән ашы уздырылды.* Г.Галиева

**УЗДЫРЫШ** *и.* 1) Уздыру эше; уздыру рәвеше. *«Дини бәйрәмнәр вакытында, уразаларда, шул табакны өйдән өйгә йөртеп, нинди генә ачлыклар, хәерчелекләр булса да, аш уздырыш иде», – дип искә ала Мәрхәбә апа.* Ватаным Татарстан

2) Алга чыгу, алдан килү өчен үткәрелгән ярыш. *Ат уздырышы. Уздырышта катнашу*

**УЗДЫРЫШТАН** *рәв.* Ярышып, узыша-узыша, башкаларны узарга тырышып. *Ул кыз алдында, ике иптәш, ярарга тырышып, уздырыштан шаяртып сөйләшеп йөрдек.* Ш.Галиев. *Төтен алкаларын уздырыштан очыралар, ирләрең бер якта торсын.* Т.Әйди

**УЗДЫРЫШУ** *ф. урт. юн. к.* **уздыру**. *Әле өч көн элек кенә ахири дусты Разил Вәлиевнең юбилеен уздырышып йөрмеш иде ләбаса.* Т.Галиуллин

**УЗДЫРЫШЫП** *рәв. к.* **уздырыштан**. *Чәчбикәләр исә, берсен берсе уздырышып, сорауларга күмә Самат дигән бу бәндәгезне.* Ф.Баттал. *Алар берсен икенчесе уздырышып мәэлдәшә – җиңүчене мактый, җиңүче тирәсендә көязләнеп боргаланырга тотынды.* Р.Мөхәммәдиев

**УЗЕЛ** I *и. рус махс.* 1) Элемтә юллары һ.б.ш. кисешкән урын. *Байкал артында безнең гаскәрләр омтылышы удар нәтиҗәсендә дошман оборонасының мөһим юллар узелы һәм көчле терәк пункты – Хайлар шәһәрен һәм тимер юл станциясен, Далай Нур күле районында Аргунь тимер юл*

*станциясен яулый һәм 20 километрга алга китә.* Мәдәни җомга

2) Оборона яки җитештерү объектлары, зур төзелешләр, мөһим эш-вакыйгалар һ.б.ш. тупланган нокта. *Немец шунда еракка ата торган пушкалар урнаштырган һәм тимер юл узелына көнен-төнен даими атып тора.* Х.Камалов

3) Үзара бәйләнгән объектлар яки системаларны берләштерү һәм шулар белән идарә итә торган үзәк; шул үзәк урнашкан бина. *Мин җирле радиодан сөйләгәндә, студия бүлмәсе вазифасын элемтә узелы башлыгы Данил ага Әгъзәмов кабинеты үти иде.* Т.Нәҗмиев

4) Нинди дә булса механизмның яки техник җайланманың бергә беркетелгән гади детальләрдән җыелган, аерым функция үтәгән бер өлеше. *Берләшмә импортны алмаштыру кысаларында «Ми» һәм «Ка» вертолётлары өчен тәгаенләнгән ВК-2500 двигательләре узелларын җитештерү программасында катнаша.* Кызыл таң

**УЗЕЛ** II *и. рус махс.* Диңгезчелектә һәм авиациядә хәрәкәт тизлеген үлчәү берәмлеге. *Корабның тизлеге биш узел булса, шобага салып корбан бирүнең кирәге дә юк икән.* М.Мәһдиев. *Моның тизлеге бик зур: кырык биш узел.* И.Хуҗин

**УЗИ** *и. рус мед.* Ультратавыш дулкыннары ярдәмендә эчке органнарны тикшереп диагностика ясау ысулы; сонография. *Бу көннәрдә өйдә торам: укыйм, язгалыйм, ә врачлар бер чиремнең серенә төшенә алмыйлар – терапевтта, невропатологта, проктологта, урологта булам. Әле рентген, әле УЗИ.* Н.Нәҗми. *Менә беркөнне, Аллага тапшырып, УЗИ аппаратыннан карату өчен консультациягә киттеләр.* Г.Галиева

**УЗУ** *ф.* **1.** 1) Атлап барып яки ниндидер транспортта берәр нәрсә турысыннан, янынннан, өстеннән үтү; күчү. *Кулы белән капшады: агачта балта эзе! Моннан кемдер узган!* А.Хәсәнов. *Бер шәһәрдә яшибез, бер урамнардан узабыз, бер һаваны сулыйбыз, бер үк зәңгәр күкне күрәбез.* А.Гыйләҗев

2) Нәрсәнеңдер түренәрәк, эчнәрәк керү, нинди дә булса ара үтү, берәр урынга хәрәкәт итү. *Фәнисә, саклык белән генә, аяк очларына гына басып, бакча түренә уза.* З.Хәким. *Ишектән шаулап-гөрләп Мәликә белән Наташа килеп керделәр дә, һич кыенсынып-нитеп тормый, эчкә уздылар.* Д.Булатова

3) Нинди дә булса юнәлештә барганда берәр нәрсәне артта калдыру, шуның аша яки яныннан үтеп китү. *Әгерҗене узганда, әллә барып та йөрмим микән дип, борылып кайтып китмәкче дә булган идем.* В.Нуруллин. *Акацияләр рәтен узып күп тә китмәдем, күзем Нократ буена төшеп китә торган баскыч янындагы ике шәүләгә төште.* В.Гали

4) Юлдан барганда яки эштә, ярышта, үсештә һ.б.ш. алга китеп, кемне дә булса артта калдыру. *Кайсыдыр бер җайдак мотоциклны узарга омтылып янга чыккан иде, чокырга туры килде бугай, егылып калды.* В.Имамов. *Мәһинур апаны узган кеше дөнья йөзендә табылмас!* Ф.Яхин

5) Нинди дә булса юнәлештә сузылу, аркылы кисеп үтү (юл, туннель һ.б.ш. тур.). *Беркадәр өскәрәк менгәч, аркылы урам уза.* А.Гыйләҗев. *Шәһәр паркы аша мәктәпкә юл уза.* А.Гадел

6) Нинди дә булса чорның яки чараның барышы, агышы, башкарылышы дәвам итү, әлдә тәмамланмау. *Кичә әнә ничек күңелле уза бит.* А.Хәсәнов. *Ә югыйсә гомер әлегә матур уза.* Р.Гаташ

7) Тавыш бирү, сайлау, конкурс нәтиҗәсендә кабул ителү, сайлану, раслану. *Югары уку йортына гариза бирде, тик конкурстан узмады.* Г.Шакиров

8) Сынау, имтихан, комиссия һ.б.ш.да әйбәт нәтиҗә алу. *Абзагыз, имтиханнарны уңышлы узып, студент та булды.* Г.Гомәр

9) Артта калу, үтү, кичү, булу (вакыт, вакыйга һ.б.). *Инде бер атна узды дигәндә, чистарткан бакчаңа колорадо коңгызы ябыша.* И.Шәрипова. *Таня үзе пычрак хатын түгел, бәйрәм узгач, өен тагын тәртипкә китерер.* З.Мәхмүди

10) Ничек тә булса, нинди дә булса нәтиҗә белән тәмамлану, үтү, башкарылу. *Көн эштә дә начар узды.* А.Гыйләҗев. *Раслау бертавыштан узды.* Ж.Дәрзаман

11) Нәрсәне дә булса өйрәнү, укып үзләштерү, нәрсә беләндер танышып чыгу. *Ниһаять, романның иң кызык җирен узгач, Рәфис тәрәзәдән карыйсы итте.* Б.Ислам. *«Фигыль» темасын узу*

12) Юкка чыгу, бөтенләй бетү (хис, кичереш һ.б.). *Ярсуым уза, баш та шәбрәк эшли башлый.* Н.Акмал. *Әдәбиятны сөю узмый.* Ш.Галиев

13) Туктау, бетү, басылу (авырту, өянәк һ.б.ш. тур.). *Ләкин күкрәгенең сул ягындагы теге сызлау узмады, кимемәде.* Н.Акмал. *Мең газапка төшкән бер ай йокысыз төннән соң өянәк узды.* Г.Ахунов

14) Билгеле бер чиктән үтү. *Автокамилләшүгә сәләтле бүгенге роботлар, ниндидер бер критик чикне узып, кешегә якынлаша, адәмиләшә башламады микән хәзер?* А.Тимергалин. *Сәгать теле, шомлы калтыранып, җидене узды.* А.Вергазов

15) Үзеннән алдагы сүз белдергән эш яки хәлнең соң, файдасыз булуын аңлата. *Эшләр хәзер куркудан узган инде...* А.Тимергалин. *Чуаркай үз башына башкорт егетләреннән әнә шул матур яңгырашлы чир йоктырып кайткан икән, үз башына: ул инде дәвалаудан узган...* М.Әмирхан. *Биредә инде эш елаудан узган иде шул.* М.Маликова

16) *юкл. форм.* Алдагы сүз белдергән нәрсә белән чикләнү, шул сыйфатта калу. *Гаҗәп, Таңсылу белән Миргазыйм арасындагы мөнәсәбәт саф дуслыктан узмады, мәхәббәт булып чәчәк атмады, ләкин икесе дә шул дуслыкка тугры булып калдылар.* А.Тимергалин. *Язганнары эпигонлыктан узмаган бик тә уртакул бу «үзешчән автор»ны, безнең арада туган-тумачалык, кодакодагыйлык, әшнәлек тамыр җәймәсә, Язучылар союзына член итеп алыр иделәрме?* Марс Шабаев

17) *күч.* Нинди дә булса яктан, берәр өлкәдә алгарак китү, өстенрәк чыгу. *Ә менә без үз республикабызда махсус әхлакый тәрбия программасын төзесәк һәм шул юнәлештә эшне башлап җибәрсәк, Россия идеологларын күпкә узып киткән булыр идек.* М.Вәли-Барҗылы. *Тиздән башка мөселманнар аларны сан ягыннан күпкә узып китә.* Казан утлары

**2.** *ярд. ф. функ.* Берәр эш барышында яки сүз уңаеннан, параллель рәвештә икенче бер эшне башкаруны белдерә; үтү. *Язучылар союзы безнең өйдә үткәргән поэзия һәм проза секцияләренең берләштерелгән утырышында иҗатларыбыз тикшерелүен әйтеп узган идем инде.* Ф.Яруллин. *Сулимов үзенең йомгаклау чыгышында «яшь иптәшнең бик томанлы ишарәләре» дип кенә кагылып узды минем сүзләргә.* М.Вәлиев

◊ **Уза китсә** Шул гына да җитмәсә, шуннан да артса, күп дигәндә. *Буларның куела торган җирләре – кечкенә генә клублар илә, бик уза китсә, шәһәр театрларыдыр.* Г.Камал. **Уза китү** Чамадан тыш арту, билгеләнгән чикләр-

дән чыгу. *Табиблар, пациентлары үлеп киткәч: «Аның авыруы уза киткән иде инде, без берни эшләтә алмадык», – дип кенә акландылар.* Шәһри Казан

**Уза бару** Акрынлап узу. *Еллар бер-бер артлы уза баралар, ә мөстәкыйльлек фикере милләттә тумый да тумый гына.* М.Миначев

**Уза башлау** Узарга тотыну. *Олы юлга чыгуыма ук, төрле ал да гөл төстәге иномаркалар мине дә яшен угы тизлеге белән уза башладылар.* А.Хәсәнов

**Уза бирү** Бернигә карамый һаман узу. *Җиһанның һәр мизгеле кайнар энә белән газаплаган шикелле көйдереп һәм көттереп уза бирде.* В.Имамов. *Ә вакыт уза бирде.* Г.Кутуй

**Уза тору** Һаман әкрен генә узу; бер-бер артлы узу. *Көннәр шулай ферма белән өй арасында йөреп уза тора.* А.Тимергалин. *Аз гына тузан ойый башлаган юлдан шофёрлар сәлам дә бирми уза тордылар.* А.Гыйләҗев

**Уза төшү** Бераз гына узу; тагын да узу. *Тавыш-гауга, җәнҗаллар уза төшкәч, шунысы ачыклана: Мөхәммәд Әминне атасы Иван III вафатыннан соң тәхеткә менгән кенәз Василий III тәкъдим иткән икән.* М.Хәбибуллин

**Уза язу** Чак узмыйча калу. *Мин хыялга чумып атлый торгач, банк урнашкан бинаны уза язганбыз.* Ф.Хуҗин

**Узып бару** Узуга табан бару, узуга күп калмау, менә-менә узу. *Шулай вакыт тиз үтә, гомер дә узып бара.* А.Гадел. *Төшке аш вакыты узып бара иде инде.* А.Фәләх

**Узып бетү** Булган берсе узу; тәмам узу. *Атлылар узып бетте, сүз җебе шуларга ялганды.* А.Гыйләҗев. *Аның дулкынлануы әле узып бетмәгән иде.* Г.Әпсәләмов

**Узып йөрү** Һәрвакыт, еш узу. *Камал театры яныннан узып йөрим.* Г.Шәйхи. *Аның яныннан еш кына узып йөри Билал.* М.Вәлиев

**Узып карау** Сынау максаты белән узу. *Шуннан соң әллә никадәр турыларыннан узып карадым, нурлы йөзләрен күрә алмадым.* Т.Гыйззәт. *Әллә соң эчкә узып карыйсы?* Л.Лерон

**Узып килү** Инде узуга табан бару. *Гариф кияү – хөр күңелле кеше. Әйе, яше кырыктан узып килүгә карамастан...* М.Мәһдиев

**Узып китү** Тиз арада узу, сиздермичә узу. *Рәсми эшләр артыннан йөреп, ай ярым вакыт узып та киткән.* Т.Галиуллин

**Узып кую** Көтмәгәндә узу. *Сакманов бай, сүзгә дә, акчага да саран түгел, ирекле көрәштә, юл куйганда, аның узып куюы да бар.* Т.Галиуллин

**Узып тору** Әледән-әле, еш кына узу. *Анда, тыз да быз килеп, бертуктаусыз машиналар әрле-бирле узып тора.* А.Хәсәнов. *Сездәй хур кызлары безнең тупса аша көн дә узып тормый.* В.Имамов

**УЗУРПА́ТОР** *и. лат.* Хакимиятне, ниндидер хокукларны законсыз юл белән үз кулына алучы зат. *Шуннан соң мөхәррир тегеңә: «Раков, син – узурпатор», – дияргә мәҗбүр була.* Г.Гомәр. *Мондый зур мәсьәләләрне трибуна артыннан, я булмаса телефон аша хәл итү урынына халыкның үзеннән аның нинди милләт вәкиле итеп тоюын референдум тәртибендә сорашу, халык теләген исәпкә алып эшләү – иң мәгъкуль нәрсә дә бит, тик нишләтәсең, ул чакта узурпаторлар уйлаган ниятнең барып чыкмаячагы көн кебек ачык.* А.Хәлим

**УЗУРПА́ТОРЛЫК** *и.* Узурпатор гамәлләре, кыланышы; узурпатор сыйфатлары; узурпация. *Бу бит инде, телисеңме-теләмисеңме, сезнең коллектив фикере белән хисаплашмавыгызны, сезнең җитәкчелек стилендә узурпаторлык чалымнары ярылып ятуын күрсәтә.* Ф.Абдуллин

**УЗУРПА́ЦИЯ** *и.* Законсыз юл белән хакимиятне яки башкалар хокукын яулап алу, үзләштерү. *Большевиклар --- узурпация ярдәмендә генә властьта кала.* Мәйдан

**УЗУРПА́ЦИЯЛӘНҮ** *ф. төш. юн. к.* **узурпацияләү**

**УЗУРПА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* 1) Нәрсәгә дә булса узурпация ясау. *Идарә итүче партия парламентта конституцион күпчелекне яулап алды. Узурпацияләде, дип үк әйтеп булмый, әлбәттә, тел бик кычытса да.* Н.Шәрифуллин. *Тәхетне узурпацияләү*

2) *күч.* Хак, хокук булмый торып, кем яки нәрсә беләндер командалык итү. *Ул чорда, дөресен әйтергә кирәк, әдәби тәнкыйть иҗтимагый фикернең дә вазифасын узурпацияләде.* Ә.Сәхапов

**УЗЫЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **узу**. *Әмма җиде километр ара, ат белән барганда, бик тиз узыла бит ул.* В.Нуруллин. *Алары – туган ил һәм халык белән бергә узылган авыр сынаулар, еллар һәм юллар истәлеге.* М.Хәсәнов

2) *з.-сыз* Сизмәстән, аңламастан узу. *Йөз, мең чакрымнар узылган.* А.Гыйләҗев

**УЗЫМЛЫ** *с. диал.* Уза торган, узып китә торган. *Ах, бу көннәр, һәрбер таңы белән Тагын яңа, тагын узымлы.* Ш.Маннур

**УЗЫНДЫРУ** *ф.* Кемгә дә булса башбаштакланырга, ярамаган, гаеп дип күрелгән нәрсә эшләргә ирек бирү, юл кую. *Бик узындырдыгыз хатыннарны, иркәләп боздыгыз, чыгырларыннан чыктылар: ирне бар дип тә белмиләр.* И.Юзеев. *Син, бердән, үзеңнең кадерле вакытыңны әрәм итәсең, икенчедән, терлек караучыларны артыгыннан узындырасың.* А.Вергазов

**Узындыра бару** Торган саен күбрәк узындыру. *Анасы Газизә --- Габдуллаҗанга тагын да назлырак булып китте кебек, җае чыккан саен, ул Габдулладан гафу сорагандай, аны артык иркәли, узындыра бара иде.* Р.Батулла

**Узындырып бетерү** Тәмам узындыру. *Өйдә эт асрыйлар, иркәләп, узындырып бетергәннәр. Түгәрәк печенье ашарга күнеккән – почмаклыны капмый!* Ш.Галиев

**Узындырып җибәрү** Соңгы арада бераз узындыру. *Әтисе белән әнисе тату торсалар да, Хәкимҗан абзый Зөһрә апаның Җәүдәтне артыграк иркәләвен, чамасызга узындырып җибәрүен өнәп бетерми, шул сәбәптән соңгы вакытларда гауга чыккалый.* А.Гыйләҗев

**Узындырып тору** Хәзер, сөйләү моментында узындыру; гел, һәрвакыт узындыру. *Күптөрле тәмле ризык ашаган, баллы сулар эчкән, авырайган малайлар, бер-берсен бүлә-бүлә, күргәннәрен Нурфыйга апаларына сөйләде. «Шулаймы, алай икән, менә бит ул», – дип узындырып торды ягымлы апа.* Р.Газиз

**УЗЫНУ** *ф.* 1) Масаю, тәкәбберләнү, үзен башкалардан өстен күрә башлау. *Әй кыландылар, әй узындылар да соң. Үземне тәмам адәм көлкесе ясадылар.* Н.Акмал. *Артык мактама, я азынып китәр.* Г.Каюмов

2) Берәр нәрсәдә арттырып җибәрү, артыгын кылану, тәртип, әхлак кагыйдәләре чигеннән чыгу. *Без сине һәр мәсьәләдә якларбыз, аңа артык узынырга юл куймабыз.* Р.Айзатуллин. *Шахтада бик узынган, имеш, пычак белән уйнаган, кеше рәнҗетүне бернигә дә санамаган.* Г.Гомәр

3) Оятсызлану, әрсезләнү, йөгәнсезләнү. *Завод хуҗаларын гына күр,*

*бөтенләй узындылар.* Мәх.Хәсәнов. *Җәүдәт, айгырга узынырга ирек бирмичә, башын күтәреп һавага сикергән вакытында, сул кулына урталай бөкләп торган солдат каешы белән аның маңгаена тондырды, артын сикертсә – артына сукты.* З.Зәйнуллин

**Узына бару** Торган саен ныграк узыну, узынуы һаман арту. *Газинур да, күзгә карап узына барган бүре малаен бераз акылга утыртып алырга кирәк, дигән уеннан кире кайтты.* А.Хәсәнов

**Узына башлау** Узыну билгеләре күренү; узынырга тотыну. *Син, Гайшә, артыгын узына башладың.* Г.Каюмов

**Узына бирү** Бернигә карамый һаман узыну. *Аларның эндәшмәвен үзенчә аңлап, Нажия аның саен узына бирде.* Н.Фәттах

**Узына төшү** Бераз узыну; тагын узыну. *Хрущёв заманында көннәр бераз «җылытып» җибәрсә дә, аның опричниклары тагы да узына төште шикелле.* Т.Мөбарәков

**Узынып алу** Аз гына, кыска гына вакыт узыну. *Яшьлек юләрлеге дип атаргамы аны, олылар әйтмешли, әткәсенең башына ашкынуы микән, Гает көннәрендә узынып алдылар шул ул елны.* Ф.Сафин

**Узынып бару** Узыну чигенә якынлашу. *Артык иркәләдек, ахры, «берләч бәрән»не, бик узынып бара.* Х.Камалов

**Узынып бетү** Тәмам узыну

**Узынып йөрү** Озак вакыт узыну. *Бик узынып йөрмә әле монда, әллә кем булып!* Ә.Фәйзи. *Райүзәккә баргач, Талип Бикмуллинны яманлап, бик узынып йөрмәсен әле дип, бераз дагалап җибәрергә уйлавымы әллә?* М.Хәбибуллин

**Узынып китү** Соңгы арада узыну. *Ләкин бу Апуш үзе турында яхшы уйлап бик узынып китмәсен, дип уйланган бер хәйлә генә иде.* М.Галәү. *Узынып киткән ерткычны сөңгечеләр сөңгегә алачаклар иде.* М.Хәбибуллин

**УЗЫШ** *и.* Узышып, алга чыгу өчен оештырылган ярыш. *Велосипедчылар программасының беренче эш көне – командалар узышы.* М.Гәрәев. *Узыш аты ни уйлый торгандыр, анысы әлегә билгесез.* Р.Кәрами

**УЗЫШЛЫЙ** *рәв.* Узып барганда, узып барышлый. *Илнең өстеннән узышлый сызгыра дошман угы, Җилгә җилбер-җилбер итә сөңгеләрнең чугы.* Г.Рәхим. *Беркөнне мин, бу йорт яныннан узышлый, әлеге матур рәшәткәнең ямен җибәреп торган бер өем чүпчарны күрдем.* Т.Нурмөхәммәтов

**УЗЫШТАН** *рәв.* Уздырышып, узардан, узыша-узыша, башкалардан уздырырга тырышып. *Җим-мазар сибә булса кирәк, су өстендәге чәчрәүле урыннарга казлар, муеннарын суза-суза, узыштан йөзеп киләләр.* Р.Төхфәтуллин. *– Иртүк торып, егерме чакрымны җәяү барып, күршеләр белән узыштан печән чабалар иде, – дип сөйли өлкән кызы, бүгенге көндә әнисен үз өендә тәрбияләүче Вәһибә апа.* Кызыл таң

**УЗЫШТЫРУ** *ф. йөкл. юн. к.* **узышу**. *Ат узыштырырга килгән кешеләр китсәләр дә зарар юк.* Г.Исхакый. *Яз җиткәч, малайлар җыелып шунда чыгабыз да уйнаклап-уйнаклап аккан гөрләвекләрдә көймә узыштырабыз.* Н.Гамбәр

**УЗЫШУ** *ф.* 1) Чабыш, йөгереш ярышында катнашу. *Кубесенчә «КамАЗ»лар чаба, юк, чапмыйлар, бер-берсе белән узышалар!* К.Кәримов. *Әти миңа: «Колыныңны хәзердән, – ди, – Сабантуйда узышырга әзерлә», – ди.* Г.Вәлиева

2) Гомумән бер-берсен узар өчен йөгерү, чабу. *Балалар узышып, төртешеп, ачык ишектән чыктылар, янәшә атлап барган атларга атландылар да күздән дә югалдылар.* Н.Фәттах

3) Алдынгылык, өстен чыгу өчен ярышу (эштә һ.б.). *Бераздан ул бирелеп, хәтта малайлар белән узышып эшләргә кереште.* Н.Фәттах. *«Иң матур тавыш миндә генә! Арада мин оста!» – дип узышалармыни?!* В.Имамов

**Узыша башлау** Узышырга тотыну. *Күп тә үтмәде, без аерым көймәләрдә бер-беребез белән узыша башладык.* Т.Нурмөхәммәтов

**Узышып карау** Сынау өчен, нәтиҗәнең ниндилеген белер өчен узышу. *Юлда извозчикларыбыз узышып карадылар.* Һ.Такташ

**УЗЫШЧЫ** *и.* Чабу, йөгерү, узышу ярышында катнашучы. *Ул дөньядагы иң популяр бу ярышларга ике ел рәттән запас узышчы булып килеп тә, ярыш кискенлеген татый алмыйча, кире кайтып киткән иде.* М.Гәрәев. *Үзенең дикъкатен көрәшчеләргә, узышчыларга, ат чабышларына юнәлтте.* М.Маликова

**УЙ** I *ы. к.* **ай** II (*1 мәгъ.*). *[Нәбиулла:] Бүсеремнең кизүе кузгалды... Уйуй, үләм!..* Т.Гыйззәт. *– Уй-уй-уй, – диде Гөлфинур, еламсыраган тавыш белән.* А.Вергазов

**УЙ** II *и.* 1) Аңны тулысынча биләп алган нәрсә; фикер. *Авырулар да тынып калганнар, аларның уйларында һәм күңелләрендә бу минутларда ниләр барын кем генә әйтә алыр икән?* Г.Әпсәләмов. *Ханбикәнең башында бер уй йөри, әмма бу хакта киңәшергә беркеме дә юк.* Ф.Бәйрәмова

2) Аң, акыл. *Уйга килгәннәр телгә килми... Тел – биктә.* А.Гыйләҗев. *Искәндәрнең кинәт кенә уйлары ачылып киткәндәй булды, ул еллар буе җанын газаплап йөргән сорауларга, ниһаять, җавап табуын аңлап, аһ итте.* Р.Вәлиев

3) Фикерләү продукты, уйлану, фикерләүнең нәтиҗәсе; идея. *«Бер уй килде әле башка, – диде Минәт, юлны күзәтүен дәвам итеп. – Командировкага әллә сине дә алырга инде?»* А.Вергазов. *Үземдә гайре табигый көч барлыгын сизгәч, мин, булачак даһиларны гына түгел, сәясәтчеләрне, фиркалы түрәләрне ана карынында чакта ук һәлак итәргә кирәк, дигән уйга килгән идем...* А.Тимергалин

4) Ният, теләк, исәп; максат. *Кунакка дип авылга кайтканда ук, балыкка төшәргә уем бар иде.* Ф.Яхин. *Аз гына ял итү уе белән ул, такта кисәгенә утырып, аркасын әрҗә кырыена терәде.* З.Хөснияр

5) Сагыш, кайгы, борчу. *Аны ниндидер хәвефле авыр уй бастымы, әллә авыруы көчәеп киткәнгәме, ул шулай күңелсез.* Р.Батулла. *Сөйләшерлек рәтем дә калмаган, уй бетерә.* Н.Гыйматдинова

◊ **Уенда да булмау** Ни дә булса эшләргә ашыкмау, җыенмау, ис китмәү. *Командирның исән калу ихтималын күпсенү ише нәрсә аның уенда да булмаган иде, ахрысы.* Х.Камалов. *Мең төрле мәшәкать синең тезгенеңне умырып тоткан, җибәрергә, ичмаса бераз гына бушатырга уенда да юк.* К.Миңлебаев. **Уй килү** Фикер туу. *Күңеленә кылт итеп бер уй килде.* А.Хәсәнов. *Минем башка кызыклы гына уй килде әле.* А.Тимергалин. **Уй тоту** Ниятләү, уйлау. *Масштаблырак эш йөртеп, кесәләреңне калынайтырга уй тоттыңмы?* В.Имамов. **Уй төшү** 1) Башка яңа фикер килү, яңа уй туу. *Менә шулчак минем күңелгә әшәке уй төште, Шәмсегаян!* А.Гыйләҗев. *Кинәт Газинурның башына шикле бер уй төште.* Г.Әпсәләмов; 2) Нинди дә булса борчу булу, хәл итүе кыен булган исәп, уй булу. *Ир башына җитди уй төшә?* А.Хәлим. *Чүлмәккә генә түгел, башкаларның башына да уй төште.* Г.Гыйльманов. **Уй(ларны) җыю** Бил-

геле бер карарга, фикергә килү. *Хәлим уйларын җыеп бетерә алмый калды, басу ягында теге аваз тагын кабатланды.* Г.Гыйльманов. **Уйга да алмау** *к.* **уенда да булмау**. *Барысын да әйтеп хат язарга, башка минем хакта уеңа да алма, дип, мөнәсәбәтләренә нокта куярга уйлады.* Ф.Яхин. **Уйга бату** Тирә-юньдәге бернәрсәгә дә игътибар итмичә, онытылып, нәрсәдер турында уйлау. *Утырамын да уйга батам.* Б.Рәхимова. **Уйга бирелү** *к.* **уйга бату**. **Уйга калу** 1) Нинди дә булса фикергә килгәнче, бераз вакыт уйланып тору. *Булачак шымчылар тартмага текәлеп уйга калды.* А.Гыймадиев. *Галәви уйга кала, убыр карчыгы сүзләре колагында яңгырый.* А.Гадел; 2) Берәр нәрсәне хәл итә алмыйча аптырап калу. *Әти, көймә читенә утырып, газета битен ачты, уйга калды.* А.Хәсәнов. **Уйга килү** Нәрсәне дә булса хәл итү өчен билгеле бер карар алу, билгеле бер фикердә тукталу. *Картлар белән киңәшләшкәннән соң, шундый уйга килдек: яңа мәчетнең аен син ясарга тиеш.* Г.Гыйльманов. *Төгәл уйга килә алмыйм, читят кешенең, төн уртасы авышкач, кое тирәсендә уралуы мөмкин түгел икәнлеген генә беләм...* А.Гыйләҗев. **Уйга талу** *к.* **уйга бату**. *Ә Марат тагын күзләрен йомып уйга талды.* Д.Гыйсметдин. **Уйга төшү** *к.* **уйга бату**. **Уйга чуму** *к.* **уйга бату**. *Барысы да, балталары суга төшкәндәй, уйга чумган.* А.Әхмәтгалиева. **Уйдан кайту** Уйланган фикердән, нияттән ваз кичү. *Ләкин Шәмси күңеле берлән һаман шуларны мөсельманча тәрбия итү уеннан кайтмады.* Г.Исхакый. *Ә Гөлбөттин бабайның егетне бу уйлардан кайтмаслык итеп ышандырасы һәм үзенең дә моңа тулысынча ышанасы килде.* Р.Гарипов. **Уйдан кичерү** Уйлап анализлау, фикер йөртү. *Бер сүз әйткән идең син миңа, Очраганда кабат кич белән. Тынгы белмим инде һич кенә, Һаман шуны уйдан кичерәм.* Ш.Галиев. *Шул вакыйгаларны уйдан кичереп, майор милиция бүлегенә килеп җитте.* Ш.Шәйдуллин

**УЙ** III *и. иск. диал.* Түбән җир, уйсу җир, иңкүлек. *Тауда йөргән бүре идем, Талчыгыма тайлы бия җиер идем; Уйга төшеп куй булдым, Куңкылдашкан күп яманга хур булдым.* Дастан

**УЙГАНУ** *ф. иск. кит. к.* ** уяну**. *Шул хәвефеннән уйганып китте, күрде: башы өстендә Дакъянус җаду хәнҗәрен чыгарып үтерергә касд иткән, һәман йөзенә бер табанча орды, Дакъянус мәтәләнеп калды.* К.Насыйри

**УЙГУР** *и.* Көнбатыш Кытайда һәм Урта Азиядә яшәүче төрки халык һәм шул халыкның аерым бер вәкиле. *Татар һәвәскәрләре оештырган андый мәҗлесләргә күзе ачыграк уйгурлар да катнашырга омтыла.* Т.Әйди. *Башта уйгур кызлары биеде, җырлады.* Р.Ибраһимов

**УЙГУРЛАШУ** *ф.* Үз милли телен һәм мәдәниятен онытып, уйгур теленнән һәм гореф-гадәтләреннән файдалана башлау, тел һәм гореф-гадәт буенча уйгурга әйләнү, уйгур булып китү. *Әйтик, кечкенә-кечкенә төркем булып, анда-монда сибелеп яшәгән милләттәшләребезнең интенсив рәвештә уйгурлаша, казакълаша барулары...* М.Госманов

**Уйгурлаша башлау** Уйгурлашырга тотыну, уйгурлашу билгеләре сизелү

**Уйгурлашып бару** Вакыт үтү белән әкренләп уйгурлашу. *Милләттәшләребезнең кайберләре теле ягыннан уйгурлашып, кайберләре казахлашып, үзбәкләшеп, кытайлашып бара.* Р.Вәлиев

**УЙГУ́РЧА** *рәв.* **1.** 1) Уйгур телендә. *Мин казахча да, кытайча да, уйгурча да җырладым, хәзер дә башкарам.* Г.Шәйхи. *Димәк, алар күбрәк уйгурча сөйләшә инде.* Шәһри Казан

2) Уйгурлар кебек, шулар гадәтенчә. *Уйгурча пешергән пылау, казакъча «аскан ит» хакында артык сөйләп торуның кирәге юк.* М.Госманов

**2.** *с. мәгъ.* Уйгур телендә булган. *Анда китерелгән борынгы төрекчә, уйгурча мәкальләрнең күбесе бүгенге татар мәкальләре белән сүзгә-сүз диярлек туры килүләре яки, мәгънәдәш булып та, тик сүзләренең генә башкачарак әйтелеше игътибарга лаеклы.* Н.Исәнбәт

**3.** *и. мәгъ.* Уйгур теле. *Ул татарча, урысча, кытайча бик яхшы белә, әмма уйгурчасы алай ук саф түгел иде.* Т.Әйди. *Бу сүз кытай теленнән маньчжур теленә, маньчжур теленнән монгол телләренә, шуннан уйгурчага, шуннан татар теленә кергән.* Р.Әхмәтьянов

**УЙГЫР** *с. диал.* Зирәк, тиз төшенүчән, тапкыр, үткер фикерле. *Уйгыр укучы*

**УЙГЫЧ** *и. махс.* Агачны уеп бизәк төшерә торган кул коралы, кискеч. *Ял иткәндә шомарткычны, уйгычны кулга алсаң, тынычландыра, ди.* Ватаным Татарстан

**УЙДЫК** *и.* 1) Уелып кергән, тирәяктагы ландшафттан астарак торган кечерәк урын. *Күп давыллар булды бу уйдыкта, Бозлар яуды, җилләр уйнады.* М.Җәлил

2) Җир яки нинди дә булса яссылык өстендә аерылып торган бер кисәк, кечкенә мәйданчык. *Күз күреме җитәр җирдә, басу уртасында сөрмичә калдырылган яшел уйдыкта зәңгәр кыр чәчәкләре күргәч, Сәбиләнең зәңгәр бизәкләр төшкән яшел күлмәге чагылып киткәндәй булды.* Р.Вәлиев

3) Бер тирәдә нәрсәнеңдер күп булып үскән урыны. *Алты-җиде чакрымга бер юл читенә ялгыз йортлар сыенган, йорт тирәләрендә әлеге дә баягы кукуруз уйдыклары, умарталар.* Д.Булатова. *Урманнарда җиләк уйдыклары, Мәтрүшкәләр бөрки хуш исен.* К.Булатова

4) Чокыр, иңкүлек, уйсулык. *Көн аязса да, җил басылмады, аяк астының да рәте-чираты юк: кая карама – уйдык та чокыр, дулкынланып яткан болганчык күлдәвек.* М.Хәсәнов

**УЙДЫ́К-УЙДЫК** *с.* **1.** Бер-берсеннән бераз ара белән урнашкан, аерым-аерым. *Аны киртләч-киртләч таулар, уйдык-уйдык яшел әрәмәләр каплап тора.* Р.Низами. *Алга баксаң – киң Идел, уңга баксаң – уйдык-уйдык болыннар, тугайлар, сулга баксаң – урман, ул офык читенә тоташа сыман.* М.Хәбибуллин

**2.** *рәв. мәгъ.* Урыны-урыны белән, тоташ түгел. *Теге әллә кайчангы вакытны казык белән казык арасыннан рәшәле үр тугаенда уйдык-уйдык үскән аклы-сарылы ромашкаларның бер көйгә салмакланып, әллә тәмле тибрәлгәннәре, әллә күзне тозлы яшь томалагандагыча эреп-эреп алулары гына калды.* Ә.Гаффар

**УЙДЫРМА** *и.* **1.** Чынбарлыкка туры килмәгән, уйлап чыгарылган, ялган сүз, хәбәр, фикер. *Егет үз уйдырмаларыннан үзе үк чирканып куйды.* А.Хәлим. *Госман белән Саматның андый уйдырмаларга исләре дә китми.* А.Гыймадиев

**2.** *с. мәгъ.* Асылы булмаган, уйлап чыгарылган, чынбарлыкка туры килми торган. *Уйдырма дошманны үтерергә түгел, ә күңелдәге нәфрәтне.* Г.Каюмов. *Шул уйдырма язманы, кош тоткандай, башка гәзитләр дә күтәреп алды, кабатлап чыгарды, тигез урында түмгәк өеп, шау-шу куптарды.* Г.Гомәр

**УЙДЫРМАЧЫ** *и.* Төрле уйдырма, асылы булмаган сүз, хәбәр уйлап чыгаручы. *Ул, татар-монголлар тарафыннан Русьны яулауның уйдырма булуын*

*расларга маташып, үзе үк шул уйдырмачыга әйләнеп китә.* Л.Закир

**УЙКУ** *и. иск. кит. к.* **йокы**. *Һич уянмый уйкусыннан, ул ята.* Г.Тукай

**УЙЛА́МАГАНДА** *рәв.* Көтмәгәндә, кинәт, искәрмәстән. *Әллә ничек уйламаганда килеп чыкты.* Г.Исхакый. *Уйламаганда, көтмәгәндә, бер ел эчендә Мөхәммәт Уразаев ялгыз калды.* Я.Зәнкиев

**УЙЛА́МАСТАН** *рәв. к.* **уйламыйча**. *Ә Диләфрүз бер дә уйламастан бу сүзләрнең теленә килүенә үзе шаккатты.* Г.Әпсәләмов

**УЙЛА́МЫЙЧА** *рәв.* Уйлап тормыйча. *Уйламыйча юкка таплыйлар бит Шатлык белән үтәр гомерне.* В.Галиев. *Әй, Юматша, Юматша, кайчак бер дә уйламыйча эшлисең син!* Г.Әпсәләмов

**УЙЛАНДЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн.* Уйланырга мәҗбүр итү. *Шагыйрь сүзләрен бүгенгегә бәйләп искә төшерү барыбер күңелдә әллә нинди уңайсыз хисләр кузгата. Һәм уйландыра да.* З.Мансуров. *Үлем аны куркыта һәм уйландыра.* А.Нәҗми

2) *з.-сыз* Уйланырга туры килү турында. *Әлеге юлларны укыгач, бүгенге күпчелек татар язучыларының хәл-хәяты хакында уйлау белән бергә, колониаль режим урнашкан чорда ук социаль һәм сәяси изелүгә дучар ителгән, күпмесе вәйран булган язучыларыбыз турында да уйландыра.* Б.Рәхимова

**Уйландыра башлау** Уйландырырга тотыну. *Иртәгә туй диген, ә. Уйландыра башлады әле.* Т.Миңнуллин. *Әбисенең «нәселне дәвам итәргә кирәк» дигән сүзләре акрынлап үтеп кереп уйландыра башлый аны.* К.Җәмит

**Уйландырып алу** Бераз гына уйландыру. *Ходай Тәгалә үз бәндәләрен яшәтә-яшәтә дә, бервакыт килеп, әнә шулай җан ачысы белән уйландырып ала икән ул.* Г.Гыйльманов

**Уйландырып кую** Бер тапкыр яки әледән-әле уйландыру. *Уйландырып куя учаклардан Утлы күмер алган шук чаклар.* В.Фатыйхов

**Уйландырып тору** Әледән-әле яки һәрдаим уйландыру. *Язучының хикәя һәм повестьлары заман сынауларын үтеп, проблемалары белән һаман да укучыны уйландырып тора, күңелен яулый.* Кызыл таң

**УЙЛАНМА** *с.* **1.** 1) Чынбарлыкта булмаган, уйлап чыгарылган. *Мондый шартларда җитәкче булып үсәргә, карьера ясарга теләгән татар үз халкының уйланма милләтчелегенә, диндарлыгына каршы көрәшергә, катнаш никахка керергә һәм бүтән әхлакый корбаннарга барырга тиеш иде.* Т.Әйди. *Уйланма бәхетнең күренер-күренмәс балкышына таба ыргылганда түгел, киресенчә, ул буш ялтыраудан качканда гына җан тынычлыгына ирешү мөмкин.* З.Хәким

2) *махс.* Теория нигезендә күзаллана торган, фараз ителә торган. *Географик полюслардан бертигез ераклыкта Җирне ике тигез ярымшарга (Көньяк һәм Төньяк ярымшарлар) бүлә торган уйланма сызык – экватор уза.* Башлангыч география курсы. *Әгәр b≠0 булса, a+bi комплекслы санын уйланма комплекслы сан дип атыйлар, аерым алганда, a=0 булганда – саф уйланма сан була.* Алгебра

**2.** *и. мәгъ.* Хыял тудырган, фараз ителгән нәрсә. *Соңгы елларда Г.Тукайга багышлап язылган пьесаларда уйланманың роле арта бара.* А.Әхмәдуллин. *Бу, әлбәттә, эпик уйланмага корылган, әмма, безнеңчә, баскак Аксак Тимергә каршы башта батырларча каршылык күрсәтелгәнлегенә ишарә итә торган бер дәлил.* М.Бакиров

**УЙЛАНУ** *ф.* 1) *кайт юн. к.* **уйлау**. *Озак уйландым инде мин бу турыда, җавабын да таптым шикелле.* Г.Галиева. *Шуннан соң мин күп уйландым...* А.Вергазов

2) *төш. юн. к.* **уйлау**. *Быел уңыш әйбәт булыр дип уйлана*

**Уйлана башлау** Уйланырга тотыну. *Ә менә хәзер үзенең бала вакытларын күз алдына китереп, шулар хакында уйлана башлады.* В.Нуруллин. *Ерактан идарә итешле машинаны «чаптырып» туйгач, Эдуард авиамоделизм турында уйлана башлады.* А.Гыймадиев

**Уйлана бирү** Һаман бер көйгә уйлану. *Мотаһир, автобуста җиңелчә генә тирбәлеп кайта-кайта, күзләрен йомып уйлана бирде.* Р.Кәрами

**Уйлана төшү** Бераз уйлану; тагын уйлану. *Әйе, эшчеләр үзбашына уйлана төшсә, начар булмас иде.* А.Вергазов

**Уйланып алу** Кыска гына вакыт уйлану. *«И чукынчык кыз, үтерә бит бу!» – дип эчтән генә уйланып алды егет.* Р.Сибат

**Уйланып җитү** Тиешенчә, кирәк кадәр уйлану. *Бу хәл тиешенчә уйланып җитте микән һәм фәнни нигезләнде микән?* М.Маликова

**Уйланып йөрү** Күптәннән, эзлекле рәвештә һәм озак уйлану. *Ул үзе дә күптәннән шул нәрсәләр хакында уйланып йөри, карт үз фәлсәфәсенә тирәнрәк кергән саен, ике арадагы уртаклык ишәя бара, аның фикеренә дә ачыклык бирә.* А.Вергазов

**Уйланып карау** Берәр нәтиҗәгә килү, чишелеш табарга тырышу өчен уйлану. *Чү!.. Кызулык белән, ачуланышу кайнарлыгы белән уйлап та, уйланып та караганы булмаган икән ич: хатынсыз ничекләр итеп яшәр икән соң ул?* З.Хөснияр

**Уйланып кую** Аз гына, кыска гына вакыт арасында уйлану. *Кайчак уйланып куям: әгәр, дим, тере фашистны күрсәм, дим, бугазыннан буар идем, дим.* М.Хуҗин

**Уйланып тору** Берникадәр вакыт уйлану. *Талия бераз уйланып торды да кәгазь-каләм алып яза башлады.* Г.Галиева

**Уйланып чыгу** Нindидер вакытның башыннан ахырына кадәр уйлану. *Шушы хикмәтегезнең очына чыгыйм дип, төне буе уйланып чыктым бит, ә...* К.Җәмит

**УЙЛАНУЛЫ** *с.* 1) Уйланып торган. *Искә төшә уйланулы чакта, тук заманда инде торсак та...* К.Сибгатуллин

2) Уйлануны чагылдырган. *Күренгәнчә, Ш.Зәки шигырьләре афористик төгәл, фәлсәфи уйланулы, тирән фикерле булулары белән аерылып тора.* М.Гайнетдин

**УЙЛАНЫЛУ** *ф. төш. юн. к.* **уйлану** (*2 мәгъ.*). *Мәсәлән, җир астыннан казып табылган бакыр без сыныклары һәм өч данә бакыр энә калдыклары безнең эрага кадәр VII–VIII меңьеллыкныкы дип уйланыла.* А.Тимергалин. *Бу вакыйгалар чылбыры алдан ук ныклап уйланылган, расланган сценарий буенча бармыймы?* А.Хәсәнов

**УЙЛА́П ТАБУ** *ф.* 1) Мәсьәләне хәл итү, авыр хәлдән чыгу юлын ачыклау. *Әһә, уйлап таптылар бугай ситуациядән чыгу әмәлен.* А.Хәмзин

2) Иҗади эш барышында моңарчы булмаган нindидер яңалык барлыкка китерү, ачыш ясау. *Кәгазьне, дарыны уйлап тапкан, гаскәрләрендә сугышчан филләре дә булган кытайлыларны куркытып торгач, Бөек стенаның бу ягында да зур көчкә, гайрәткә ия халык, ыру, кабилә яшәгәндер, диясе килә.* А.Хәсәнов

**УЙЛА́П ТАБУЧЫ** *и.* Иҗади эш нәтиҗәсендә моңарчы булмаган яңалык барлыкка китерүче, ачучы. *Дөрес, Нуриҗан да тарта алыр иде бу вазифаны, ләкин ул – менә дигән инженер, рацио-*

*нализатор, уйлап табучы.* З.Мурсиев. *Әйтик, шул ук тәгәрмәч уйлап табучының теләге кабул булды: кешеләр хәзер капчык күтәреп йөрми, алар арба тарта һәм, җае чыккан саен, иҗатчыга рәхмәт укыйлар.* М.Кәбиров

**УЙЛА́У** *ф.* 1) Уйларны кемгә яки нәрсәгә дә булса юнәлдерү, уй йөртү, фикерләү. *Озак уйлады, озак баш ватты Җәүдәт һәм, Аликның бердәнбер ышанычлы коралы, көче – үзе шикелле тәҗрибәсез, беркатлы үсмерләр, дигән фикергә килде.* А.Гыйләҗев. *Ул инде бүреләр хакында уйламый.* Г.Гыйльманов

2) Нинди дә булса караштa, фикердә тору; санау, исәпләү. *Гайбәтләргә ышанып, аны дошман дип, хыянәтче дип уйлыйммы?* Я.Зәнкиев. *Моның өчен, мөгаен, республиканың берәр эчкәреге төбәгенә бару кирәктер, һәрхәлдә, мин шулай уйлыйм.* Т.Әйди

3) Нәрсә дә булса эшләргә җыену, ният итү. *Теге көнне мин килгәнне Ләйсирәгә әйткәннәрдер шул... Шуңа күрә килергә уйлагандыр инде ул...* М.Вәли-Барҗылы. *Ул яңадан «Сарман»ны башларга уйлаган иде, ләкин уеннан кире кайтты.* А.Хәлим

4) Фикерләрне туплау, акылда берәр мәсьәләне хәл итү юлларын эзләү, карарга килергә әзерләнү. *Моңа кадәрге имтиханнарда ул үзен тыныч тотты, җавабын уйлап, ашыкмыйча бирде.* Г.Әпсәләмов. *Ул моны урынлы дип тапты. Ләкин хәл кылыр өчен, бу мәсьәләне уйларга, нечкәләп өйрәнергә кирәк, диде.* М.Әмир

5) Кемдер, нәрсәдер өчен борчылу, кемне, нәрсәне дә булса кайгырту. *Үзеңне уйламасаң, мине, балаларыңны уйлар идең!* Н.Гаетбай. *Ат җене кагылмагандыр бит?! Укуыңны уйла...* В.Имамов

◊ **Уйламаган җирдән** Кинәт кенә, көтмәгәндә. *Менә ул уйламаган җирдән тукталып кала, әйдә, тиен күрсәтәм, ди, биш-алты адым эчкә керә һәм агач башына күрсәтә.* Г.Рәхим. *31 е көнне уйламаган җирдән бөтенләй ят кешеләр килеп керде.* Ф.Яруллин. **Уйлап тормастан** Уйламыйча, тиз генә. *Хәмит, аны-моны уйлап тормастан, ике озын, бер кыска звонок бирде.* Җ.Дәрзаман. **Уйлап чыгару** 1) *к.* **уйлап табу**. *Хәзерге вакытта инсаниятнең алгарышы зыялылар эшчәнлегенә турыдан-туры бәйле: туфракны зыялылар уйлап чыгарган машина эшкәртә, игеннәрне ура-җыя, ташый, саклый, ипи пешерә.* А.Тимергалин; 2) Булмаганны, юк нәрсәне сөйләү; уйдырма чыгару. *Бәлки, әнисе, аны үсендерү өчен, үзе генә уйлап чыгаргандыр моны, алар, өлкәннәр, кызык халык бит...* А.Хәлим. *Каян уйлап чыгарасыңдыр җыен тузга язмаганны?* А.Әхмәтгалиева

**Уйлап алу** Тиз генә, аз гына вакыт эчендә уйлау. *«Чирләмәсә, чибәр генә буласы икән бу бала», – дип уйлап алды ул.* Х.Мөдәррисова

**Уйлап бетерү** Нәрсәнедер ахырына кадәр уйлау; әллә никадәр уйлар уйлау, уйларда ниндидер чикләрдән чыгу. *Фәннур әле бусын уйлап бетермәгән иде.* А.Гыймадиев. *Шушы көннәрдә, тез күмәчемне саклап ятканда, мин әллә ниләр уйлап бетердем...* А.Гыйләҗев

**Уйлап җиткерү** Тиешле дәрәҗәдә, ахырына кадәр уйлау. *Хикмәт шунда ки, мәсьәләнең күп очракта без уйлап җиткерми торган катлаулырак яклары да бар.* М.Госманов

**Уйлап карау** Төрлечә, төрле уйлар уйлау; ниндидер нәтиҗәгә килү, нәрсәгәдер җавап табу максаты белән уйлау. *Уйлап караганың бармы: бу җыркәйләрдән ни калыр, әгәр дә ки теләсә кем кулына җыр тапшыра башласаң?* Ф.Сафин. *Газинур көтмәгәндә генә килеп туган бу җитди проблеманың теге ягын да, бу ягын да кат-кат уйлап карады.* А.Хәсәнов

**Уйлап кую** Аз гына яки тиз генә уйлау. *«Тагын бер шайтан таңы», – дип, ачынып уйлап куйды Әхмәтсафа.* Ф.Сафин

**Уйлап тору** Хәзер, әле, сөйләү моментында уйлау; бертуктаусыз уйлау. *Муса Мәскәүгә китте, укырга. Университет дип хыяллана. Әле үзем дә уйлап торам: әллә Мәскәү ягына китәсе...* Ф.Сафин. *Койрыгым уйнап тора, Башым гел уйлап тора. Кем икәнемне белмәсәң, Тавык, үрдәктән сора.* Н.Әхмәдиев

**Уйлый башлау** Уйларга тотыну. *Әхмәтсафа инде, язмышына буйсынып, шушы якларда төпләнү ягын да уйлый башлады.* Ф.Сафин

**Уйлый төшү** Тагын бераз уйлау. *Уйлый төшкәч төшенде егет: җәй буе сыерлар белән телсез аңлашып, аның теле ялкауланган икән һәм, бәлки әле, зиһене дә.* Ә.Баян

**УЙЛАШУ** *ф. урт. юн.* Кем беләндер бергә, киңәшләшә-киңәшләшә уйлау. *Алдан уйлашканча, монда, куып килсәләр-нитсәләр юлны саташтырырга дип, Сибгать дус төшеп калырга тиеш иде.* А.Шамов. *Риза булсаң, хәзер үк алып калам, әгәр инде, уйлашырга кирәк, дип әйтәсең икән – көтәргә дә була.* В.Нуруллин

**УЙЛЫ** *с.* 1) Билгеле уе булган. *Тереклеккә үсү дәрте, күктәге яктылык шәменә омтылыш бирелгән икән, димәк, һәммә нәрсәнең дә канатлы җаны, уйлы күңеле бар.* М.Галиев. *Кем саф күңелле, изге уйлы – шул гына хуҗа булырга лаеклы.* А.Гадел

2) Уй йөртә белгән, уйлый белгән. *Ә Садыйк Сираевич – уйлы кеше. Уйлы булмаса, ул бүгенгесе көндә шушындый дәрәҗәгә ирешмәгән дә булыр иде.* З.Хөснияр

3) Уйчан, уйга бирелүчән, күп уйлаучан; озак уйлый торган, икеләнүчән

4) Борчуы булган; кайгылы. *Баш, уйлы кешенеке төсле, гел аска тарта, ком тутырган кебек авыр, җитмәсә.* Г.Әпсәләмов. *Дамира уйлы башын учларына алды, аның артка тарап куелган куе тыңлаусыз чәчләре алга ишелеп төшеп, йөзен каплады.* Р.Габделхакова

5) Уйчанлыкны чагылдыра торган. *Гадәттә дә нык каешланган каты кулы бүген бөтенләй тимер кебек авыр, уйлы күзләрдә бүген ачу гайрәте кайный кебек күренде.* Г.Ибраһимов

**УЙМА** *и.* 1) Уелып кергән, батып, чокырланып торган урын. *Аның йөзенә хәсрәт сеңгән иде, туты тагын да каралган, күз уймалары тирәнәйгән, югыйсә мондый чокыраю ханбикәбезгә хас түгел, дала баласы бит ул.* М.Хуҗин

2) *диал.* Идән астындагы базга төшү өчен эшләнгән уем; шул уемны ябу һәм ачу өчен эшләнгән такта япма. *Өйгә кайтып килсәм, ни күзем белән күрим: уйма такталары ачык тора.* Ш.Камал

**УЙМАК** *ф.* Тегү теккәндә энә тишмәсен өчен бармак башына киелә торган эче куыш металл әйбер. *Гадәттә, шәкертләр аңардан гел анысын-монысын сорап торалар, чөнки аның үз кулы белән ясаган каеш тупсалы, әрҗә сыман сандыгында мәдрәсә тормышы өчен кирәк бөтен нәрсәсе: энәсе дә, җебе дә, уймагы да, безе дә, --- хәтта җилем белән балавызы да саклана торган иде.* Ә.Еники

◊ **Уймак авыз** Бөрелеп торган, кечкенә һәм түгәрәк иреннәр турында. *Менә шунда инде Факиһәм бер «җенләнеп» ала. Уймак авызларын бүлтәйткәләп мине мыскыллый башлый.* Д.Зөбәерова. **Уймак хәтле (чаклы, кебек, кадәр)** Бик кечкенә әйбер турында.

*Башка иптәшләре ничек җавап бирергә белмичә калтырап утырганда, ул иң беренче булып билет ала да уймак кадәр фикерне йомгак зурлыгында итеп уратып-уратып сөйләп ташлый иде.* Ф.Яруллин. *Һәрнәрсәгә ис китеп, исле-иссез чәчәктән исереп, уймак хәтле хәсрәттән көеп, уймак чаклы бәхеткә сөенеп, дөньяны һаман шул сабый күңел белән күргән ваемсыз чаклар чигенә барды...* Д.Зөбәерова

**УЙМАКЛАНДЫРУ** *ф.* Уймак кебек итү, уймакка охшату, түгәрәкләндерү; бөрү. *Кылдан нечкә кашлары өскә күтәрелеп китте, ул, үтә кызыл авызын уймакландырып, сул кулын күкрәгенә куйды ---.* А.Расих. *[Разия] бер-бер артлы соравын биреп, бит уртасы чокырларын уймакландырып елмаеп ала.* Г.Ахунов

**УЙМАКЛАНУ** *ф.* 1) Чокыраеп китү, батып керү. *Көлгән чакта бит алмалары уймакланып, тагын да чибәрләнебрәк китә, сүзләрен каушамыйча, кыю итеп әйтә торган шул кыз Миңнулланың күңел түренә әнә шул чакта кереп утырды.* В.Нуруллин

2) Бөтерелү, уралу (су агымы тур.). *Көннәр, уймакланып аккан елга кебек, тиз-тиз ага торды...* А.Гыйләҗев. *Елгачык чуерташлар өстеннән сырланасырлана йөгерә, тик яр култыгына кергән урыннарда гына ул тирәнәеп китә, караңгылана төшкән чырай белән ашыкмыйча, уймакланып ага.* Ә.Еники

**Уймакланып китү** Кинәт уймаклану. *Ә алардан егерме-егерме биш метр читтә, елганың уймакланып киткән урынында, өч киек үрдәк чума-чума суда уйный.* Г.Әпсәләмов

**Уймакланып тору** Уймакланган хәлдә булу. *Узган көздәге кебек, Сәнҗәрә аттан төште, бүре җиләге куагы төбенә тезләнде; тамыр казып алынган чокырчык инде күмелгән, уймакланып кына тора, яфрак түшәлгән шул уймакка кар суы җыелган.* Л.Зөлкарнәй

**УЙМАКЛАП** *рәв.* 1) Уймак белән, уймак күләме белән. *Бөтенләй рәнҗеп карады ир: шулай уймаклап эчәргә тиешме ул, авыз пычратып торганчы, эчмәгәнең мең артык.* К.Кара

2) *күч.* Әзләп-әзләп, кечкенә күләмнәр белән. *Уймаклап бүлеп чыгу*

**УЙМА́К-УЙМАК** *с.* Урыны-урыны белән урнашкан, аерым-аерым торган кечерәк кенә түгәрәкләр рәвешендәге. *Эчкәре кергән саен, уймак-уймак аланнар, бөдрә куаклыклар, стенадай баскан агачлар тезмәсе.* Р.Низамиев. *Кара тукымадагы уймак-уймак түгәрәкләр ут яктысында мәрҗән кашыдай ялтырый, меңләгән очкын чәчрәтә.* Г.Гомәр

**УЙМА́КЧӘЧӘК** *и. бот.* Сыраҗчалар семьялыгыннан яфраклары эллипс формасында булган, эре чәчәкләре сары, кызыл сары, җете кызыл төсләрдәге күпьеллык яки икееллык дару үсемлеге; бармакчык; *русчасы:* **наперстянка**. *XIX гасырда ук француз химигы Леройе уймакчәчәктән (наперстянка) агулы матдә аерып ала һәм аны «дигиталис» дип атый.* Агулы үсемлекләр

**УЙМАЛАНУ** *ф.* Уелып керү; уем хасил булу. *Әле уңда, әле сулда калкып күренеп барган яшел таулар, болын буйлап уймаланып сузылган талтирәкле инеш – барысы да нәкъ үзе!* Р.Төхфәтуллин

**УЙМАЛЫ** *с.* Уелып кергән, батып, чокырланып торган. *Тау буйлары уймалы, Басып торып булмады.* З.Мәхмүди

**УЙМЫР** *и.* Уем, җек кебекләрне ую өчен, йөзе сабына перпендикуляр торган тар гына балта төре; аркылы балта. *Агачка чигү чиккәнгә охшатып, уймыр белән ясалган челтәрле бизәкләрне, чуарлап эшләнгән өлгеләрне күргәч, Иргали сөенергә дә, көенергә дә белмәде.* Мәхм.Хәсәнов. *Иренмәсә дә иренми икән кеше! Пычкы, уймыр белән чигү чигә икән. Әнә капка түбәсендә калай әтәч канат кага.* Казан утлары

**УЙНАК** *с.* 1) Уенчак, шаян. *Сәер табыш, сискәндереп, өнсез итте, уйнак малай әверелде мәэюскә.* З.Мансуров. *Шуннан соң гына, уйнак тай шикелле, кыр өстенә сыпырдым.* Р.Гариф

2) Уйнап тора торган, хәрәкәтчән. *Тәбәнәгрәк буйлы, янар чәчле, олпат кыяфәте йөзенә чыккан бу уйнак күзле абый төрле хәлләрне сөйләп тә күрсәтә иде инде!* М.Хуҗин. *Тик торамыни инде уйнак туп!* Н.Каштанов

3) *күч.* Җиңел һәм матур. *Кинәт егет уйнак, көр тавыш белән: – Җә инде, телефон чыбыгында сандугач сайратма, – диде.* Н.Гыйматдинова

4) *күч.* Хәрәкәт юнәлешен җиңел генә һәм тиз үзгәртә торган. *Фани дөньяның тышкы бизәге булган алмагачлар --- шау чәчәккә күмелгән; уйнак җил исә, гомерләрнең мәңгелек түгеллеген искәртергә теләгәндәй, ап-ак таҗларны, тузгытып, аяк астына түшәргә дә өлгергән.* А.Әхмәтгалиева. *Бит кызарткан уйнак җилдән Яңа ел исе килә.* Л.Шәех

**УЙНАКЛАТУ** *ф.* 1) Хәрәкәтләндереп алу, селкетеп кую. *Киң каеш эшлияләр белән матурлап җигелгән көр ат арбаны уйнаклатып кына, эһ тә итмичә, җиңел генә тартып бара.* А.Гыйләҗев. *Иртәнге җил асылынып торган тирелә рне җиңел генә уйнаклата.* К.Җәмит

2) Очкынландыру, уйнату (күзләр тур.). *Сары чәчләре меңләгән вак, сырга сыман бөдрәләр белән калтыранган, бер күзе – бер, икенчесе гүяки икенче басуда урак урган күзләрен уйнаклаткан Алевтина Петровна белән Сөендек өйрәнелгән алымнар белән эчеп җибәрделәр.* А.Хәлим. *Гөлтуташ күлмәк изүеннән алып бөгәрләнгән кәгазь тоттыруга, Зифа аңа күз йөгертеп кенә чыкты да, күзләрендә очкын уйнаклатып, шундук ярып салды.* В.Имамов

**Уйнаклата башлау** Уйнаклатырга тотыну. *Рәшат, яңгыратып, шәрык көен уйнатып җибәрде, кыз, шарфына уралып, тәнен уйнаклата башлады.* М.Маликова

**Уйнаклата төшү** Тагын уйнаклату; бераз уйнаклату. *Аннары тавышын чак кына уйнаклата төшеп, янә сүз башлады ул: – Гаҗәп хәл!* М.Хәсәнов

**Уйнаклатып алу** Аз гына, кыска гына вакыт эчендә уйнаклату. *Көтмәгәндә кулларын күтәрде дә кызгылт чияләрне бармак очларында уйнаклатып алды.* В.Имамов

**Уйнаклатып җибәрү** *к.* **уйнаклата башлау**. *Әйтик, болай да сыгылмалы гәүдәсен артык уйнаклатып җибәрергә тырыша. Ныграк игътибар итсеннәр, янәсе.* С.Поварисов

**Уйнаклатып кую** Тиз генә, аз гына уйнаклату. *Назлы җыр йөрәк ашкынуын баса алмады, күрәсең, Шамил, яткан җиреннән кузгала төшеп, дилбегәне уйнаклатып куйды.* В.Имамов

**Уйнаклатып тору** Дәвамлы, озак уйнаклату; хәзер, сөйләү моментында уйнаклату. *Гаскәриләрчә төз гәүдә, нәрсәдер әйтәсе килеп төбәлгән сөйкемле кыю караш, акыллы киң маңгай, аҗаган шикелле, берничә көн күңелне уйнаклатып торды да тагын шул аҗаган шикелле үк юкка да чыкты.* Д.Зөбәерова

**УЙНАКЛА́У** *ф.* 1) Уйнап чабу, сикергәләп йөрү. *Син, уйнаклап, таудан төштең, күктә сайрады тургай.* Р.Фәйзуллин. *Ир белән хатын шәһәр читендәге бакчаларына җыена, янннарында кечкенә кызлары уйнаклап йөри.* Кызыл таң

2) Җиңел атлап йөрү; төрле хәрәкәтләр ясап бару, очу һ.б. *Калкавычлары да чумгалап ала, эләккән һәм җепкә тезелгән балыкларым күз алдымда – суда уйнаклыйлар.* Ф.Баттал. *Акчарлаклар уйнаклыйлар, төшеп монда.* Р.Гаташ

3) Төрле төсләргә кереп җемелдәү, ялтырау, төсләр уйнау. *Әйе, чыннан да, өстәлемдә Сәйдәшевләрнең әйтерсең лә теге дөньядан әйләнеп кайткан зур сәгате ята иде: --- аның җиз теле һәм циферблатының коршавы ялтырый, ә калын пыяланың кыйгачлап эшкәрткән кырыйларында салават күпере төсләре уйнаклый.* А.Тимергалин. *Ике яклап, тыгыз булып тезелгән тирәкләр һәм юкәләр ябалдашында кичке кояш кызыллыгы уйнаклый.* Р.Вәлиев

4) *күч.* Төрле хәрәкәтләр ясау, кисәк хәрәкәткә килү. *Робертның бугаз төене кызу-кызу уйнаклап алды.* Р.Төхфәтуллин. *Сорауны ошатты булса кирәк, экскурсоводның нәзек кашлары уйнаклап алды.* М.Әмирханов

5) *күч.* Ялт-йолт килү, очкынлану; бер урында туктап тормыйча гел хәрәкәт итү, уйнау. *Ләкин эчке тавышы: «Ышанма бу адәмгә, күр, күзләре ничек уйнаклый», – дип кисәтте.* М.Әмирханов

6) *күч.* Хәрәкәт юнәлешен җиңел һәм тиз үзгәртеп тору, тигезсез хәрәкәт итү. *Кыйшык йортымда җилләр уйнаклый... Кайда торырмын, ул ишелеп аугач, Бирерме Ходай сипләрлек агач?* Ә.Рәшитов

**Уйнаклап алу** Тиз генә, кыска гына вакыт арасында уйнаклау. *Кармагыңа киерткән җимеңне читеннән генә эләктереп, башта аның бер уйнаклап алганын көт.* А.Хәсәнов

**Уйнаклап китү** Кинәт кенә уйнаклау. *Әллә ничек кенә күңеле уйнаклап китте шул: гомере үтеп бара, шул көнгә кадәр аягына бер юньле итек тә алып кия алмаган икән әле...* Г.Гыйльманов

**Уйнаклап кую** *к.* **уйнаклап алу**. *Зөфәрнең йөзе берьюлы бүртенеп китте, күзләре кысылып калды, яңак сөякләре уйнаклап куйды.* Ә.Еники

**Уйнаклап тору** Уйнаклау процессында булу; әледән-әле уйнаклау. *Йөргәндә, Уйминныкы шикелле, аның гәүдәсе уйнаклап тормый.* С.Поварисов. *Днепр өстендәге дулкыннарда кораблар уйнаклап тора.* В.Имамов

**Уйнаклап яту** *сөйл.* Уйнаклау процессында булу. *Күпмегә сузылган булыр иде бу газап, чыдый алган булыр идеме ул, юкмы, әмма томаланган, шашырга җиткән күзләре алдында кинәт җемҗем уйнаклап яткан түп-түгәрәк, зур бер күл ачылды.* Ә.Еники

**Уйнаклый башлау** Уйнакларга тотыну. *Күзләре уйнаклый башлый, йөзе нурланып китә.* Г.Әпсәләмов. *Ике-өч минут үтүгә, Фәләхнең болай да чамасыз нык борчулы күңеле тагын да ныграк уйнаклый башлады.* В.Нуруллин

**Уйнаклый бирү** Бернигә карамый һаман уйнаклау. *Анасыдай чуар бозауга кызык кына: койрыгын колгадай өскә катырган да кырын-кырын сикергәләп уйнаклый бирә.* А.Вергазов

**Уйнаклый төшү** Бераз уйнаклау; тагын уйнаклау. *Үзенең зифа буе, тулы гәүдәсе, калку күкрәге белән бераз уйнаклый төшеп килде дә, егеткә карап, кулларын алды, баягы сүзләр кабатланды.* Г.Ибраһимов

**УЙНАКЛЫК** *и.* 1) Уйнак (*1–2 мәгъ.*) булу, шуклык, уенчаклык. *Җырчы тавышындагы уйнаклык, нур, җиңеллек образны күз алдына китерә дә бастыра.* Т.Әйди

2) Җиңеллек, йөгереклек. *Көтәкөтә бик зарыгып, Суның хәле киткән: Салмак җәелгән дә ага, Уйнаклыгы беткән.* Б.Рәхимова

**УЙНАЛУ** *ф. төш. юн. к.* **уйнау**. *Артык күп уйналган спектакльне алмаштырырга кирәклеге, «Ак калфак» урынына бүтән кием кияргә вакыт җиткәнлеге телгә кереп кабатлана торганлыктан, Ильясның кәефе кырыла, йөрәге сулкылдап куя.* Ә.Баян

**Уйнала башлау** Уйналырга тотыну. *Тагы музыка гөрелдәде, болгарларның «Агач башы» дигән көе уйнала башлады.* Г.Исхакый. *Ул чорда азәрбайҗан сәхнәсендә төрле дини сюжетлардан торган композицияләр (мистерияләр) уйнала башлаган.* К.Гыйззәтов

**Уйнала килү** *к.* **уйналып килү**. *Ләкин өстәгеләр бу шикаятьләргә үсеп китәргә юл куймады, спектакль, сәхнәдән төшмичә, еллар буе уйнала килә.* Р.Батулла

**Уйнала тору** Әледән-әле уйналу; башка эш-гамәл белән бер үк вакытта уйналу. *Йоклап киткән мизгелләре дә була. Үзе йоклап утыра, гармуны уйнала тора...* Ш.Галиев. *Әсәрне укый бардым, шул ук вакытта күз алдымда спектакль дә уйнала торды.* Ф.Ибраһимов

**Уйналып алу** Аз гына, кыска гына вакыт уйналу. *Ул уенчак күңелле өрәктән соң санитарлар күз алдында тагын бер фаҗигале кәмит уйналып алды.* Ш.Маннур

**Уйналып бетү** Уйналу тәмамлану. *Көй уйналып беткәч, дәрвиш елан авызыннан кураен алып баш ия.* А.Гадел

**Уйналып калу** Уйналырга өлгерү. *Аны Академия театрына алгач, пьеса репертуардан төште, илле тапкыр гына уйналып калды.* И.Юзеев

**Уйналып килү** Күптәннән даими рәвештә уйналу. *Пьеса гасырдан артык даими уйналып килә.* М.Хуҗин

**Уйналып тору** Гел, һәрвакыт яки әледән-әле уйналу; хәзер уйналу. *Калган пьесаларым Әлмәт, Минзәлә, Чаллы дәүләт театрларында, Уфаның «Нур», Казан яшьләр театрларында уйналды һәм уйналып тора.* Ф.Яруллин

**УЙНАП** *рәв.* 1) Җитдилек белән, чынлап түгел, шаярып, болай гына. *Сабир да бу сүзләрнең уйнап әйтелгәнен сизеп алды.* А.Алиш. *Зөләйха апаның уйнап сөйләшмәгәнен белмәсәк, бу хәбәргә беребез дә ышанмас иде, ышандык: көтмәгәндә уч төбем кычыта башлады.* А.Гыйләҗев

2) Бик җиңел генә, зур тырышлык яки көч куймыйча, рәхәтләнеп. *Ул герне югарыга таба уйнап күтәрә, һәм 24 килограммлы авыр тимер кыз кулында мамык кына сыман булып күренде.* Ютазы таңнары

**УЙНА́П-КӨЛЕП** *рәв.* Күңел ачып, күңелле итеп. *Уйнап-көлеп бара торгач, килеп җиткәнебезне сизми дә калдык.* Б.Ислам. *Гел шундый бул: без синең уйнап-көлеп, шаярып йөрүеңә ияләнгән.* Г.Галиева

**УЙНАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **уйнау**. *Әгәр инде ул өйдә булса, карчыклар аны чакырып сөяләр, сөйләштерәләр, кызлар аны үзләренең уеннарына катыштыралар, аны, кыстап, курай уйнаталар иде.* Ф.Әмирхан. *Башта бер-ике сәгать буе моңлы-сагышлы музыка уйнаталар.* М.Шабаев

2) Ярыш, лотерея, шобага һ.б.ш.ны отучыларга бүләк итеп кую. *Соңрак телевизордан гына белдек: сәүдә үзәгендә акция икән, фатир, машина уйнаталар, имеш.* Д.Гыйсметдин

3) Музыка уен коралында нәрсә дә булса башкару. *Нәни генә бер кыз баланың авыз гармуны уйнатып утыруы барысыннан да бигрәк кызыктырды.* Г.Бәширов

**Уйната башлау** Уйнатырга тотыну. *Менә ул, буявы саргаеп кыршылган радиоланы ачып, татар көйләре уйната башлады.* М.Маликова

**Уйната бирү** Бернигә дә карамастан һаман уйнату. *--- болар уртасында башына укалы бүрек кигән, чуар кием өстеннән кара алтынлы кәмәр буган, --- камыш буйлы бер җегет, кулындагы камчысын уйната биреп, көлә-көлә нидер сөйли.* Г.Ибраһимов. *Шул сүздән соң, янә сәхнә артына борылып, йодрыгын уйната бирде: – Чүпрәкбаш! Кибәкбаш!* Ә.Баян

**Уйнатып алу** *к.* **уйнатып кую**. *Ничек кенә үзен кулга алырга тырышса да, бу халәттән арына алмыйча, беравыкны ишек яңагына сөялеп тын гына торды, шик-шөбһәне коеп төшерергә теләгәндәй, калын тун эченә яшеренгән сөякчел җилкәләрен уйнатып алды һәм, җиңеләя төшеп, директор бүлмәсенә алдан үзе керде.* А.Вергазов

**Уйнатып җибәрү** *к.* **уйната башлау**. *Миләүшәнең сүзләре аның хыялын уйнатып җибәрде.* Ф.Яруллин

**Уйнатып йөрү** Озак вакыт дәвамында уйнату. *Берчак минем үземә дә эләкте үзбәкләрдән, өлкән буын кылыч уйнатып йөргән өчен...* Г.Гомәр

**Уйнатып карау** Сынау өчен уйнату. *Башта Салих миннән элек өйрәнгән көйне уйнатып карый, аннары үзе берәр яңа көйне уйнап күрсәтә һәм шуны миңа нота буенча кат-кат уйнарга куша.* Ә.Еники

**Уйнатып килү** Күптәннән эзлекле рәвештә уйнату. *Медицина дөньясы минем хыялымны күптәннән уйнатып килә иде.* Г.Әпсәләмов

**Уйнатып кую** Бер тапкыр уйнату. *– Миндә булсамы мондый сылулык, типтереп яши белер идем, – дип, мәгънәле кыяфәт белән кашларын уйнатып куйды.* Т.Галиуллин

**Уйнатып тору** Хәзер, әле уйнату; дәвамлы, озак уйнату. *Кулындагы дәфтәрне алмыйча, аны җилпәзә кебегрәк уйнатып торуына дикъкать итсәң, нindидер четерекле нәрсә барлыгын чамаларга мөмкин иде.* Ә.Баян

**УЙНАТЫЛУ** *төш. юн. к.* **уйнату**. *Ләкин ул вакытта, бәгъзы билгеле сәбәпләр аркасында, пьеса уйнатылмый калды.* С.Ибраһимова. *Минә быргылар уйнатылды, халык җыелды, игъланны кычкырып укыдылар, мондагы такырбашларның колагына керде инде ул.* Ә.Еники. *Акциядә 10 таба, 3 фотоаппарат һәм иң зур бүләк – телевизор уйнатылды.* Сәхнә

**Уйнатыла башлау** Уйнатылырга тотыну. *Ниһаять, социаль ипотека программасы буенча күптән көтелгән фатирлар уйнатыла башлады.* Шәһри Казан

**Уйнатылып бетү** Ахыргача уйнатылу. *Чират буенча чыгарылган 890 фатир әлегә уйнатылып бетмәгән.* Ватаным Татарстан

**Уйнатылып килү** Күптәннән даими рәвештә уйнатылу. *Шунысын да әйтик: моңа кадәр уйнатылып килгән кубок, өч ел рәттән җиңгәннәре өчен, нефтьчеләргә гомерлеккә тапшырылган иде, һәм яңа трофейны да беренче булып алар отуга ирешә.* Дуслык

**Уйнатылып тору** Даимән яки әледән-әле уйнатылу; хәзер, әле уйнатылу. *Бәйрәм саен телефоннар, планшетлар, сюрпризлар уйнатылып тора*

**УЙНАТЫП** *рәв. к.* **уйнап кына**. *Әнә гер күтәрүче Альберт Галимов та, 48 яшендә булуына карамастан, 16 килолы ике герне, уйнатып, 86 тапкыр күтәрде.* Э.Шәвәлиева

**УЙНА́У** *ф.* 1) Вакытны күңел ачып, шаярып, уен белән үткәрү. *Өйалдында балалар уйный, чыр-чу.* Ш.Галиев. *– Ания, минә бу уенчыклар белән уйный тор син, яме, – дип, Саимә кухняга чыгып китте.* Г.Галиева

2) Билгеле кагыйдәләргә нигезләнгән отышлы, спорт яки башка шундый уен белән мәшгуль булу. *Син һәр эшне оста эшли идең, хәтта качышлы уйнаганда да таба алмый идек без сине.* М.Хуҗин. *Ул кичне Бикташ Кашкарыйга атланып йөрмәде, малайларның футбол уйнаганын карарга да бармады.* М.Маликова

3) Нинди дә булса кагыйдәле уенда нәрсәдәндер файдалану, нәрсә беләндер йөрү. *Уен тузы белән шәп уйнадык.* Н.Хәсәнов

4) Музыка уен коралында нинди дә булса көй чыгару, нәрсә дә булса башкару. *Муса, кызып-кызып уйнаган җиреннән гармунын туктатып, Дәшмәснең аркасына сул кулы белән китереп шапылдатып суга.* З.Зәйнуллин. *Ул, кларнетта һәм саксофонда уйнап, бәгырьләребезне телгәләде.* Т.Нәҗмиев

5) Нинди дә булса музыкаль әсәр башкару (оркестр, радио һ.б.ш. тур.). *Эчтән ят телдә өзеп-өзеп җырлаган тавыш ишетелә: магнитофон уйный.* М.Маликова. *Еракта оркестр уйный.* А.Гыйләҗев

6) Сәхнәдә, кинода нindидер образ булып чыгыш ясау, роль башкару. *Миләүшә йөз-кыяфәте белән дә, матур итеп җырлавы белән дә класста Галиябану ролен уйнарлык иң кулай кыз иде.* З.Хөснияр. *Бу спектакльләрне оештыруда Фатих Әмирхан төп җитәкче генә түгел, бәлки үзе дә баш рольләрне уйный.* М.Мәһдиев

7) Нәрсә беләндер җитди шөгыльләнмәү, кыяфәт чыгару, кемдер булып кылану. *Бу арбалар да чын түгел, атлар да уенчык кына, үзебез дә зурлар булып уйнап шаярабыздыр кебек тоелды.* А.Гыйләҗев. *Моңа Татарстан мөстәкыйльлек яулаган елларда милләтче булып уйнап, тора-бара эшчәнлекләре һәрнәрсәдә һәм һәркемдә каралык, пычрак эзләү белән чикләнгән кайбер кемсәләрнең шәһәр мөселман дөньясын болгатырга маташуы да сәбәп булгандыр.* Туган як

8) Җиңел генә төрле-төрле хәрәкәтләр ясап чабу, сикергәләү, очу һ.б.ш. *Бөтен җирдә күбәләкләр уйный, бал кортлары, төклетуралар безелдәп йөри, чәчәк исләре аңкып тора.* Г.Бәширов. *Колыннары уйный янәшә.* С.Гәрәева

9) Кулларны тик тотмау; кулдагы нинди дә булса әйберне максатсыз әйләндерү, хәрәкәтләндерү, селкетү. *Бармактагы йөзек белән уйнау. Стакандагы балкашык белән уйнау. Төймәләре белән уйнау*

10) Нәрсәне дә булса тиешле максатларда түгел, уенчык итеп куллану, нәрсә беләндер шаяру. *Ут белән уйнама – көярсең.* Әйтем. *Пычак белән уйнарга ярыймыни соң, ахмаклар.* Ә.Хәсәнов. *Җиде яшендә, шырпы белән уйнап, колхозның салам түбәле лабазын яндырган иде ул.* И.Сабиров

11) *куч.* Төрле юнәлештә зур тизлек белән хәрәкәт итү; нәрсәнедер төрле якка очыру (табигать көчләре һәм күренешләре тур.). *Ком бураны тузмагае, Җилләр уйный ыжгырып. Хәвеф-хәтәр чыкмагае, Утырмагыз сызгырып...* Л.Шагыйрьҗан. *Шул көнне, үч иткәндәй, кичкә таба дүрт яктан кара болыт килеп, авыл өстендә янә давыл уйнады.* М.Вәлиев

12) Нәрсәнеңдер өстендә чагылып җемелдәү; төрле төсләргә кереп ялтырау, елкылдау; төрле шәүләләр булып хәрәкәтләнү. *Егеткә якынлыктан, аның тәне кыза, каны кайный, йөзендә алсу кызыллык уйный, иреннәре тәмләп кызарып киләләр, күзләре яшь йөрәкнең әллә кай җирләреннән кайнап чыккан бер дәрт белән елмаялар иде.* Г.Ибра-

һимов. *Аллы-гөлле төсләр уйный бар галәмдә, Ай, йолдызлар бәйрәм итә күк илендә.* Т.Миңнуллин

13) *күч.* Кемгә яки нәрсәгә дә булса уенчык итеп карау; кемнеңдер теләге белән исәпләшмичә эш итү, үз максатларында куллану. *Һәм бары тик уйнама хис белән.* Р.Мөхәммәтшин. *Төкердең син минем хисләремә! Уйнадың, уйнадың да ташладың!* С.Зыялы

14) *күч.* Чырай, тавыш һ.б.ш. үзгәртеп тору, уйнаклау. *Бераз чатанласа да, чурт с ним, күзләре уйнап тора.* А.Хәсәнов

15) *күч.* Уй-хисләр алмашынып торып чырайда чагылу. *Аның йөзендә, күзендә шатлык уйный башлады.* Г.Исхакый. *Салих Сәйдәшев карашында ниндидер үзгәлек бар кебек. Ара-тирә күзендә шундый тирән сагыш уйнап ала. Ниндидер гаҗәеп зур югалтуга дучар булган кешедә генә була торгандыр мондый караш.* Ф.Сафин

16) *күч.* Актив эшчәнлек хәлендә булу (хис, хыял, фикер һ.б.ш. тур.). *Кайсы кеше белән сөйләшкәндә фантазияң уйный, сүзгә сүз ялганып, көтелмәгән кызыклар туа.* Ш.Галиев. *Ибраһимовның кәефе күтәрелә, хыялы уйный, иҗат фантазиясе ныклап эшли башлый.* М.Хәсәнов

◊ **Уйнап кына** Артык көч куймыйча, бик җиңел итеп. *Көзгедәй ялтырап торган төрәннәр кара карга канаты шикелле чем кара, симез туфракны уйнап кына актаралар.* Г.Әпсәләмов. *Юан-юан бүрәнәләрнең бер башыннан ике-өч кеше күтәрсә, икенче башыннан Сафуан берүзе генә күтәрә, һәм ул аны уйнап кына, җиңел генә күтәрә сыман.* З.Мәхмүди. **Уйнап кына тору** Ниндидер эш бик җитез һәм җиңел эшләнү. *Аның кулында пычак уйнап кына торды.* Н.Фәттах. *Кулында эш уйнап кына тора иде!* Ә.Сафиуллин

**Уйнап алу** Кыска гына вакыт, аз гына уйнау. *Әллә тагын качышлы уйнап алабызмы?* К.Кәримов. *Аның өчен әллә Рифат килгән иде, әллә инде җил ишек белән уйнап алды – барыбер кебек тоелды.* А.Мансуров

**Уйнап бетерү** Уйнауны ахырына җиткереп туктау. – *Афәрин! – диде Габбас Батталович, мин уйнап бетергәч.* Г.Гомәр

**Уйнап җибәрү** *к.* **уйный башлау**. *Көтүче шул курайны кисеп алган да уйнап җибәргән.* А.Гыйләҗев. *Бер дә кирәксезгә оркестр уйнап җибәрде, җиз торбалар һәм барабан тавышы колакларны ярды.* В.Имамов

**Уйнап йөрү** Озаклап уйнау. *Әле Сәрияләр белән курчак театры уйнап йөрисе бар, кул чабуларны ишетеп куанасы бар.* А.Тимергалин

**Уйнап карау** Сынау максаты белән уйнау. *Мәүлиха апалар капка төбенә барып уйнап кара син, кәшәкәңне тартып алып сырт буйлап берне сылар!* А.Гыйләҗев. *Бездән өч-дүрт яшькә зуррак Шайтан Вагыйз дигән малай, кая, кубызыңны уйнап карыйм әле, дип, сагыз урынына ябышты бит Рәдифкә.* В.Нуруллин

**Уйнап кую** Аз гына һәм тиз арада уйнау. *Гармунчы көйнең дүрттән берен боргалый-боргалый уйнап куя.* М.Мәһдиев. *Күз алдында очкыннар уйнап куйды хәтта.* Ф.Баттал

**Уйнап ташлау** Чамадан артык уйнау. *Кайбер артистлар, артыгын уйнап ташлап, рольдән чыга алмыйм әле, дип йөриләр.* Безнең гәҗит

**Уйнап тору** Уйнау процессында булу; әле, хәзер уйнау. *Акрын гына музыка уйнап тора.* М.Әмирхан. *Класстәшлары Талип аларга баянда уйнап торды.* Б.Камалов

**Уйнап чыгу** Башыннан ахырына кадәр уйнау. *Дилбәр бер бармак белән «Галиябану»ны ялгыш-йолгыш уйнап чыга.* К.Тинчурин. *Төне буе йокламый уйнап чыгабыз.* М.Яһүдин

**Уйный бару** Һәрберсен рәттән уйнау. *Шулай итеп пьесалар языла торды, артистлар уйный барды, тамашачылар да йөрмәде түгел, йөрде.* Л.Ихсанова

**Уйный башлау** Уйнарга тотыну. *Ул кичтә болай да бик тырышып уйнаган гармунымны тагын да моңлырак, тагын да тәэсирлерәк итеп уйный башладым.* В.Нуруллин

**УЙНАШ** *и.* Өйләнешмәгән ир белән хатын арасындагы женси мөнәсәбәт; зина, фәхешлек. *Яшьли чая булды һәм яшьли уйнаштан бала тапты.* Г.Рәхим. *[Фәнзия] уй-хәсрәтләрен чыгарып салды: – Инде ничәмә-ничә еллар эчәсең. Түздем. Чит-ят хатыннар белән чуалдың. Түздем уйнашыңа да. Бала-чага хакына түздем.* З.Зәйнуллин

◊ **Уйнаштан туган** 1) Никахсыз ата-анадан туган, зинадан туган, җилдән туган. *Мәсәлән, Геракл ул – Зевсның уйнаштан туган малае бит.* З.Хөснияр. *Шәһәрдә яшәүче уйнаштан туган кызына йорт җиткергән, автомобиль алып биргән.* М.Әмирхан; 2) Мәсхәрәләп сүгенү сүзе. *Әй син, уйнаштан туган хайван, синнән сорыйм, кем үтерде, дим?* Р.Сәгъди. *Халыклары эттән ач, беттән ялангач заманда галәмгә тимер-томыр ыргытып, байлык туздырып уйнаганнар бит, уйнаштан туган нәрсәләр!* Ф.Баттал

**УЙНА́Ш ИТҮ** *ф.* Никахсыз женси мөнәсәбәттә булу, зина кылу. *Ире, төн уртасында өеннән чыгып, кем беләндер уйнаш итеп йөргән хатын бәхетле була аламы?* М.Кәбиров. *Апаң өстеннән туктамастан йөреде, уйнаш итте.* З.Зәйнуллин

**УЙНА́Ш КЫЛУ** *ф. к.* **уйнаш итү**. *Бәлки, уйнаш кылганы өчен күкләрнең җәзасы булгандыр.* Н.Әхмәдиев. *Көне-төне күңел ачалар да чагыр эчеп уйнаш кылалар.* Н.Фәттах

**УЙНАШЛЫК** *и. к.* **уйнаш**. *Мәхәббәтнең бар шул үз чоры! Чоры үткәч, никтер «уйнашлык» дип Атала ул, каһәр суккыры!* Ш.Җиһангирова

**УЙНАШЛЫ́К ИТҮ** *ф. к.* **уйнаш итү**. – *Асраулар әйберләрне урлый, приказчиклар белән уйнашлык итә, ә син берни белмисең... – дип, хатынына ябырылды.* М.Галәү

**УЙНАШЛЫ́К КЫЛУ** *ф. к.* **уйнаш итү**. *Госпитальдә ятканда, миңа сеңлем Сәлимә Гашия җиңгәңнең ир-атлар белән уйнашлык кылуы турында хат язган иде.* Ә.Моталлапов

**УЙНАШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **уйнау**. *Аларның күзләренә келәт янында җиккән ат тора кебек булды, лапас башында бер көтү малайлар уйнаша кебек тоелды, капка төбендә тирән-тирән упкынлы баз казылган кебек сизелде.* Г.Исхакый

2) Уйнаклау, төрле җитез хәрәкәтләр ясау. *Су буенда үскән зәңгәр чәчәкләр өстендә аллы-гөлле күбәләкләр уйнаша.* А.Нургатина. *Әнә, агачларда тиеннәр уйнаша, шуны күзәтәм, әткәй...* Т.Нәбиуллин

3) Төрле төсләргә кереп ялтырау, жемелдәү, төсләр уйнау; уйнаклау. *Атилла хан өстәлдә янып торган шәмдәлләргә игътибар итте: каршы яктагы чатыр чүпрәгенә төшкән шыксыз күләгәләр уйнаша, шыксыз хәрәкәтләр ясыйлар.* М.Хәбибуллин. *Эшчеләр кулында зәңгәр, көрән, кара төстәге тиреләр уйнаша.* К.Кәримов

**Уйнаша башлау** Уйнашырга тотыну. *Балалар да үзара уртак тел таптылар кебек: коридор буйлап куыша,*

*чыркылдашып уйнаша да башладылар.* Л.Ибраһим-Вәлиди

**Уйнаша бирү** Һаман уйнашу. *Әмма перронда су җыелып хасил булган ак күбекләр һаман сикерешеп уйнаша бирә.* Р.Ибраһимов

**Уйнашып алу** Аз гына уйнашу. *Тамаклар карлыкты, баш очыбызда йодрыклар да уйнашып алды.* Ф.Яруллин

**Уйнашып тору** Озаклап уйнашу. *Төрле шарлатаннар белән кыланып, уйнашып торырга вакыт юктыр.* Г.Исхакый

**УЙНАШЧЫ** *и.* Уйнаш итүче, зина кылучы кеше; зиначы. *Шуның шикелле, хәзрәте Исхак заманында уйнашчыларның берсе ишәккә, берсе тәвәгә әверелгән, дигән сүзләр дә бар китапларда.* К.Тинчурин. *Беләсеңме, яшьтәш, мин менә АКШ белән Германия кебек илләрне, валлаһи, уйнашчы бичәләр кебек күрәм.* Д.Бүләков

**УЙНАШЧЫЛЫК** *и.* Зиначылык, уйнаш. *Икенчедән, бүген аның фәрештәдәй мәгъсум дусты Мәрьямнең пакь намусы шул юкны күзәтеп йөргән адәм тарафыннан уйнашчылык пычрагына батырылу ихтималы бик якынаеп калды.* Г.Ибраһимов. *Әйтик, белүемчә, күп халыкларда һәм урысларның үзләрендә дә төрле диндәге кешеләрнең катнаш никахка керүе уйнашчылык, фахишлек дип бәяләнгән.* Ф.Баттал

**УЙНАШЧЫЛЫ́К ИТҮ** *ф. к.* **уйнаш итү**. *Ә соң аның, хатыны була торып, качып-посып, балдызы Миңсылу белән уйнашчылык итүенә ничек карарга?* С.Хафизов. *Гаять чибәр, ләкин ирен санга да санамаган, җиңел холыклы, чит ирләр белән уйнашчылык иткән хатын күбәләк кыяфәтенә кергән.* Казан утлары

**УЙСУ** *с.* Әйләнә-тирәдәге тигез җирдән чокыраебрак торган, иңкү, иңкел. *Әйдә, дустым, озат мине Уйсу җиргә җиткәнче.* Җыр. *Әнә киң яланнар, әнә уйсу болыннар, әнә зур урманнар – һәммәсе яшәреп утыралар.* Г.Ибраһимов

**УЙСУЛАНУ** *ф.* Уйсуга әйләнү; уйсу булып тору. *Мәгыйзь бу хикмәтле заводны хәтерли иде әле. Аны гына түгел, Колан Кыр белән Гәр Хутор уртасындагы «алпавыт дачасы»н да, Кесмәс елгасының уйсуланып аккан тугаен да, наратлы тау башын да – барысы да тарих.* М.Мәһдиев

**Уйсуланып тору** Уйсу хәлдә булу. *Түгәрәк йөзенең бит урталары уйсуланып тора, елмайганда ул уйсулык, тирәнәеп, нәни генә чокырчыкка әверелә һәм кызга аерым бер сөйкем өсти.* Н.Әхмәдиев

**УЙСУЛЫК** *и.* Уйсу җир, иңкүлек, иңкеллек. *Моннан бик үк ерак та түгел, урманыбыз артында, уйсулык бар.* Н.Сәйяр. *Рәфис, үзенә дәшкән малайны күрергә теләп, ялангач калкулык өстеннән караганда Актай белән олы юл арасында уч төбедәй төсмерләнгән уйсулык ягына борылды.* А.Вергазов

**УЙСЫЗ** *с.* Гамьсез, ваемсыз, кайгысыз. *Ниндидер уйсыз, хиссез бер хәлдә утырды ул.* Г.Әпсәләмов. *Әй ул вакытның уйсыз, борчусыз бәхете!* Манс. Вәлиев

**УЙСЫЗЛЫК** *и.* Гамьсезлек, ваемсызлык, уйлап башны катырмау. *Суфия басып торган җир уйсызлык, фикерсезлек чүленә әверелә барды.* С.Гаффарова

**УЙЧАН** *с.* **1.** 1) Уйга бирелгән, тирән уйга чумган, шундый халәттә булган; моңсу. *Тауга менеп карасаң, хәзер Иртеш аръягындагы болыннар, болында янган учаклар, учак тирәли утырган уйчан кешеләр ап-ачык күренәдер.* Я.Зәнкиев. *Син бит башка, син гел уйчан идең.* Р.Вәлиев

2) Уйчанлык чагылып торган, уйчанлыкны белдергән (күзләр, чырай тур.). *Уйчан зәңгәр күзләре кысылып калган хәтта.* Җ.Рәхимов. – *Чөнки кеше – дөньяның үзе кебек катлаулы һәм каршылыклы ул,* – *диде уйчан тавыш белән Мөдәррис.* М.Маликова

3) *күч.* Тыныч, шау-шусыз, хәрәкәтсез. *Безнең уйчан авыл кырларында Бакралар чәчәк атканнар.* Н.Баян. *Һәм без киттек уйчан урамнардан, уйнамадың бүтән нигәдер...* Ф.Сафин

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Уйга бирелеп, тирән уйга чумып. *Җанын талкып, артык йөдәтмә син уйчан калган ялгыз кешене.* Р.Фәйзуллин. *Нурислам, ияге белән учына таянып, шактый ара уйчан торды, аннары башын күтәрде.* Р.Вәлиев

2) Моңсу булып, тирән уйга калгандай булып. *Ләкин йөзе һаман уйчан күренә.* Г.Әпсәләмов

**УЙЧАНЛАНУ** *ф.* 1) Уйга бирелү; уйга чуму. *Гөлгенә кинәт уйчанланды, бу халәтен Нәҗипкә сиздерәсе килмәде.* А.Гыйләҗев. *Беренче күрешүдән түгел, акрынлап, көннәр үткән саен, карлар эреп, көртләр арасыннан авыл өйләре күренеп, ягымлы көяшы белән назлап җиргә яз килгән саен моңсуланды, сабырланды, уйчанланды Лира.* Г.Мирһади

2) Уйчанлыкны чагылдыра башлау, моңсулану (күзләр, чырай тур.). *Ибраһим җайлап утырды, йөзе уйчанланды.* В.Имамов. *Карашы уйчанланган һәм ниндидер бер аңлаешсыз күләгә белән өретелгән иде.* Ф.Садриев

3) *күч.* Тынычлану, тынып калу; ямансу булып китү. *Яз буе, җәй буе ашыгып-ашыгып яши дә авыл, менә шушы октябрь ахырларында картларча тынып кала, уйчанлана.* М.Мәһдиев

**Уйчанлана бару** Торган саен ныграк уйчанлану. *Шаянлыгы, чытлыклыгы белән җиде елдан артык укытучыларны интектергән, директор бүлмәсеннән башы чыкмаган Гомәр сигезенче классның икенче яртыеллыгында акрын-акрын уйчанлана барды һәм уку елы беткәндә инде тәмам моңаеп калды.* Г.Рәхим

**Уйчанлана башлау** Уйчанлану билгеләре сизелү. *Аның миңа төбәлеп уйчанлана башлаган чыраена яктылык иңә, калын йомшак иреннәре елмая, күзләре чаткыланып нур бөрки.* Г.Ахунов

**Уйчанлана төшү** Тагын да уйчанлану; бераз гына уйчанлану. *Тез башларын гына түгел, бөтен кыяфәтен – сөрмәле күзләрен дә, хуш исле чәчләрен дә, уйчанлана төшкән, әмма бәхетле көлемсерәгән йөзен дә, ничектер үсебрәк киткән нечкә-сылу гәүдәсен дә апачык күреп торам кебек...* Ә.Еники

**Уйчанланып бару** Торган саен уйчанлану. – *Күңелле була иде!* – *дип, уйчанланып барган юлдашына карап алды.* Ф.Яхин

**Уйчанланып калу** Нинди дә булса тәэсирдән соң уйчанга әверелү. – *Ул сәгать кая китте икән?* – *диде дә уйчанланып калды Азат.* А.Тимергалин

**Уйчанланып китү** Соңгы арада уйчанлану. *Егет кеше түзә. Бер түгел, ике-өч шигыре чыккач та түзә, тик уйчанланып кына китә.* М.Мәһдиев

**Уйчанланып тору** Берникадәр вакыт уйчанланган хәлдә булу. *Бераз уйчанланып торганнан соң, Рәмзия тагын дәртләнеп сөйләп китте.* Г.Гыйльманов

**УЙЧАНЛЫК** *и.* Тирән уйларга чуму гадәте; уйланып тору халәте. *Сәримә иреннәрен тешләде, түфли үкчәләре белән саргайган каен яфракларын изгәләде, йөзендә уйчанлык сирпелеп алды.* Д.Каюмова. *Мондый минутларда Мәрьям абыстай сүзсез уйчанлыкка төшә, хәлсез бушлык аны янә акрын гына йота башлаган кебек була.* Ә.Еники

**УЙЧЫ** *и. иск.* Озаклап уйлаучы, тиз генә эшкә тотына алмаучы кеше. *Уйчы уй уйлаганчы, тәвәккәл судан үтеп китәр.* Мәкаль

**УК** I *и.* 1) Җәядән ату өчен, нечкә, төз, каты материалдан бер башына очлы, гадәттә, металл башак беркетеп ясалган корал. *Калкулык башына менеп җиткән һәркем чүлмәкне әйләнеп үтә һәм, бер ук таягын эләктерә дә, алдын-артын карамыйча, кирегә йөгерә.* Н.Фәттах. *Җәя бавын киереп тарткач кына, җәядән сызгырып ук чыга...* А.Гыйләҗев

2) Төрле үлчәү җайланмаларында, сәгатьләрдә һ.б. шкаладагы зурлыкны күрсәтү өчен хезмәт итә торган тар һәм озын пластина. *Спидометр угы 130 турысында дерелдәп тора...* З.Фәтхетдинов. *Азимутны билгеләгәндә, компасны угының кара башы төньякны күрсәтерлек итеп урнаштыралар.* Башлангыч география курсы

3) Берәр юнәлешне күрсәтү өчен, бер очына кысынкы почмак ясап кыска гына ике сызыкча ясалган озын сызык формасындагы шартлы билге (→). *Җир өслегендә еллык явым-төшем күләменең бүленеше картада – изолинияләр, ә җилләр юнәлеше уклар белән күрсәтелгән.* Материклар һәм океаннар географиясе

4) *махс.* Күтәрү кранының хәрәкәтләнә торган өлеше, шулай ук авыр йөкләр күтәрү өчен махсус җайланма. *Менә кран угы әллә ничә катлы биек йортның түбәсенә менеп җитте дә туктап калды.* Р.Вәлиев

5) Бал корты, шөпшә, чаян һ.б.ш. чага торган бөҗәкләрдә саклану һәм һөҗүм итү әгъзасының кадый торган өлеше; чага, чаккыч. *Бал кортының угы файдалы, Нурулла.* Н.Гыйматдинова. *Кулын тыгып, кәрәзнең кайдалыгын белүе була – икенче тишектән чыккан күч моңа сарыла. ...Тәненнән йөздән артык корт угы алганнар.* Ә.Зарипов

6) *сөйл.* Агулы еланнарның очы икегә аерылган озын теле. *Аның елан угыдай тел очы морожный өстендә яшен тизлеге белән хәрәкәт итә иде.* А.Гыйләҗев. *Тик бер сүздән йөрәгемә кинәт Караелан угы үрелде.* Р.Вәлиева

7) *геогр.* Берәр сулык ярында су агымы ярдәмендә өелеп хасил була торган тар һәм озын борын. *Арабат угы*

8) *күч.* Җанны әрнетүгә, күңелгә тиюгә юнәлтелгән чәнечкеле, усал, төртмә сүз һ.б. *Әгәр дә мин әйткәнне белсәләр, минем күземне ачырмаслар, бөтен зәхмәт укларын миңа кадый башларлар.* Г.Камал. *Тәнкыйть һәм сатира уклары кадимчеләргә охранка котыртуыннан башка да яуган булыр иде, мөгаен.* Р.Зарипов

◊ **Ук кебек** 1) Күз иярмәслек тизлек белән; яшен тизлеге белән. *Бер мизгелдән ул да, ук кебек томырылып, кызчык артыннан чаба иде.* А.Әхмәтгалиева. *Булат җан ачысы белән кычкырып җибәрде һәм ук кебек ишегалдына атылды.* В.Нуриев; 2) Төз һәм тип-тигез. *Урман тиз-тиз аларга каршы чаба башлады, ук кебек сузылып яткан киң юл буп-буш иде.* А.Гыйләҗев

**УК** II *кис.* 1) Рәвешләр белән килеп, «шактый», «бик», «үтә» мәгънәсендә кулланыла. *Хәлең әлегә начар ук түгел, өметең исән диган сүздер бу.* Ә.Баян. *Ачыргаланып кычкырган каз кабат Бурсык елгасы ягына таба очты, ерак ук китте.* Н.Хәсәнов

2) Үзеннән алда килгән сүзнең мәгънәсенә басым ясау, көчәйтү өчен, «хәтта» мәгънәсендә кулланыла. *Фәрит дигәннәренә шул җитә калды – кычкырып елап ук җибәрде.* Р.Сәгъди. *Хихылдап көлеп, сызгырып ук җибәрделәр хәтта.* С.Шәрипов

3) Юнәлеш килешендәге исемнәр белән килеп, соңгы чиккә, нәкъ янына барып җитүне аңлата. *Әнвәр белән Гүзәлия кичләрен боргаланып аккан Актайның сөзәк ярында яфраклары суга ук тиеп үскән юан, биек өянке янына килеп утыра башладылар.* Ә.Хәсәнов. *Абыйапалар икенче атнага ук ясатып алып килергә вәгъдә бирделәр.* Р.Галиуллин

4) Фигыльләрнең инфинитив формасыннан соң килеп, эшнең, хәлнең шуңа барып җитүен белдерә. *Ул инде мине ачуланырга ук керешә: – Маңкорт син, вәт!* З.Мәхмүди. *Шулай да кыз машинага кереп утырырга ук базмады.* К.Тимбикова

5) Чыгыш килешендәге исемнәр һәм рәвешләрдән соң килеп, эш-хәрәкәтнең шулар белдергән урыннан, вакыттан башлануын, эшләнүен аңлата. *Түр бүлмәдәге кәнәфигә ятып телевизор караучы Галимҗанына берни әйтмичә, капкадан ук чыгып китте.* К.Тимбикова. *Икенче көнне таңнан ук киттем шундагы базарга чыгып.* Ф.Баттал

6) Урын-вакыт килешендәге исемнәрдән соң килеп, «төп-төгәл шул вакытта», «нәкъ шул урында» дигән мәгънәне белдерә. *Җыелышның нинди уңай белән чакырылганын хәзер инде хәтерли алмыйм, ләкин башта ук әзерләнеп килгән чыгышымның көн тәртибенә сыйганын яхшы хәтерлим.* Ә.Еники. *Басуда ук күрдем мин аның машинасын.* З.Мәхмүди

7) *-ганчы, -канчы* формасына беткән хәл фигыльләрдән соң килеп, нинди дә булса эшнең нәрсәдәндер алдарак уйлануын, үтәлүен һ.б.ш. аңлата. *Ул өчпочмаклар пешеп чыкканчы ук китәргә җыена башлады.* Ф.Яруллин. *Сәгатегезне пароходка утырганчы ук югалткансыздыр может, ә?* Ә.Еники

8) *-канда, -ышлый* формаларыннан соң килеп, «шул эш барган вакытта, шуннан да калмыйча» мәгънәсен бирә. *Ул әле шуыша башлаганда ук яраланган иде, ләкин, бөтен көчен җыеп, сугышчыларыннан калышмаска тырышты.* Г.Әпсәләмов. *Нindирәк нәрсә икән дип, кайтышлый ук кылларын чиртkәләп карады.* В.Нуруллин

9) *-гач, -кач* формасына беткән хәл фигыльләрдән соң килеп, кинәтлек, тизлек төсмерен белдерә. *Шуннан кайткач ук авырып егыла һәм ике-өч көннән соң дөнья куя.* Ә.Баян. *Димәк, Кави кулга алынгач ук, Галимҗан Ибраһимовка тотынганнар.* З.Зәйнуллин

10) Кайбер алмашлыклардан соң килеп, нәрсәгәдер охшашлыкны, тәңгәллекне, нәрсә беләндер бердәйлекне белдерә. *Булды, булды, тынычлан, алай ук борчылырга әлегә сәбәп юк.* Р.Сәгъди. *Чөнки үзем дә нәкъ менә шундый ук ялгыз, гаиләсез һәм баласыз кеше булгач, артык тәэсирләнеп киткәнмендер.* Л.Шагыйрьҗан

11) Кайбер алмашлыклар һәм рәвешләрдән соң килеп, эш-хәлнең төгәл урынын, вакытын күрсәтә, «нәкъ» мәгънәсендә кулланыла. *Үзәнбай ерак бит, анда ук качмагандыр әле.* Ә.Баян. *Шунда ук бер тәгәрмәчен җуйган уенчык йөк машинасы.* А.Тимергалин

**УКА** *и. гр.* **1.** Гадәттә алтын яки көмеш җепләрдән катнаштырып эшләнгән, кием бизәү өчен кайма, чук, чачак һ.б.ш. итеп кулланылган тасма яки җеп. *Сандыктан буй-буй зәңгәр сатин күлмәген ала. Ука белән чиккән камзулын кия.* А.Хәсәнов. *Луиза ишеккә атылып бара, китабы бер якка, ука читле башмаклары икенче якка оча.* А.Гыйләҗев

**2.** *с. мәгъ.* Алтын яки көмеш җепләрдән ясалган. *Иңбашларына куелган өр-яңа, көнгә дә рәтләп күренмәгән кызыл читле ука эполетлар, уңнан сулга*

*таба ука бау белән асылындырып тагылган көмеш саплы нәфис кылыч --- Искәндәрне хикәяләрдәге шаһзадәләр кыяфәтенә кертеп, --- гайрәт кылларын чирткәндәй хис иттерәләр иде.* К.Тинчурин. *Яшь кызлар башларына калфак киеп, аның өстеннән ука чачак бәйләгәннәр.* Ф.Баязитова

◊ **Укасы коелган кебек (сыман)** *к.* **балтасы суга төшкән кебек**. – *Сиңа ни булды, наныем? Укаң коелган кеше сыман йөрисең? – дип сорады.* А.Гыйләҗев. **Укасы коелу** *ирон.* Кәеф кырылу, күңел төшү; үпкәләү. *Белмәссең, югыйсә кеше теленә керүең, начальник кешенең укасы коелуы бар.* Ф.Хөсни. *Әллә инде шәһәрдән кайткан хан кызының укасы коелыр диеп курыктыңмы?* М.Вәли-Барҗылы. **Укасы коелмас** *кимс.* Бернинди зыян күрмәс, бернәрсәсе бозылмас, берни дә булмас. – *Клубка чыгып биеп кайтканнан укаң коелмас әле, – дип әйдәкли башлагач, аңа ияреп, кичләрен яшьләр арасында үткәрә башлады.* А.Әхмәтгалиева. --- *бая ук хушлашып китсә, укасы коелмас иде әле.* Д.Бүләков. **Укасы уңмас** *к.* **укасы коелмас**. *Күңел өчен генә күзгә-башка күренеп китсә, укасы уңмас иде бит.* Г.Ахунов

**УКАЗ** *и. рус* 1) Югары хакимият органының, монархның яки президентның закон көченә ия булган карары. *Хәзер сезгә Жихарев әфәнде патша галиҗәнапларының бөек указын игълан итәр.* В.Имамов. *Президент указы чыгасы гына калды.* Д.Шәйхетдин

2) Совет чорына кадәр дин әһелләренә, имамлык итүләрен таныклап, мөфтият тарафыннан раслана торган рөхсәтнамә. *Тикшергәч, чыннан да, никах укылган чакта кызның ике ае тулмаганлык беленде, шуның аркасында мулланың указы алынды.* Г.Ибраһимов. *Сабирҗан мөәззиннең указы юк иде.* М.Галәү

3) *күч.* Боерык, әмер, күрсәтмә. *Мин кешегә, нәрсә эшләргә тиеш син, дип указ бирә алмыйм, андый хокукым юк.* Безнең гәҗит

**УКА́ЗКА** *и. рус* Күрсәткеч таяк. *Өстәлдән указка алып, бүлмә уртасына, макеты янына чыгып басты.* М.Маликова. *Әти кулындагы указкасын өстәлгә ыргытты да, ишекне тибеп кенә ачып, бүлмәдән чыгып китте.* А.Хәсәнов

**УКАЗЛЫ** *с.* Указы (*2 мәгъ.*) булган, указ алган. *Указлы мәхдүмебезгә, сорасак, төрек солтаны да кызын бирер иде, сорамадык кына.* К.Тинчурин. *Безнең Алпарга өйләнмәгән указлы мулла җибәрделәр.* Н.Гыйматдинова

**УКАЛА́У** *ф.* Ука белән бизәү, ука тоту. *Әфичәрләр якасына кызлар ука укалый, тагын да бер набор булса, кызлар сука сукалый.* С.Баттал. *Яшел бәрхеттән укалап теккән Бохара чапаны, Төркиядән кайтарткан ак шәлъяулык, Арчада теккән укалы читек һәм егерме биш тәңкә көмеш булачак, Алла боерса.* А.Гадел

**Укалап бетерү** Укалау эшен төгәлләү; барысын да укалау

**Укалап кую** Алдан яки тиз арада укалау

**Укалап чыгу** Булган берсен берәмберәм укалау. *Тасмалар белән укалап чыгарга*

**Укалый башлау** Укалау эшенә керешү

**УКАЛЫ** *с.* Ука белән бизәлгән, ука тотылган. *Түрдә кирәгәдә бер укалы бүрек белән бер яшел чапан асылып тора иде.* Г.Ибраһимов. *Өсләренә укалы чибәр камзул, аякларына болгар читекләре кигән, башларына аллы-гөлле яулык бәйләгән байбичәләр төркеме дә агыла.* С.Поварисов

**УКАЧЫ** *и.* Ука белән чигү остасы. *Шәйхи ике кулдашы, укачы һәм сәдәпчесе белән кара өйдә урнашты.* М.Әмирханов

**У́КБАЛЫК** *и. зоол. к.* **кылычбалык**. *Укбалык --- ау вакытында үзләренең табигый коралларыннан – кылычтан файдаланалар. Кылычлары белән алар балыкларны яралыйлар яки үтерәләр.* Кызыклы ихтиология

**УКБАШ** *и. зоол. к.* **сөйрек**, **севрюга**. *Матур итеп көмеш кашык, чәнечкеләр, бәллүр савытлар белән бизәлгән өстәлдә җаның теләгән ризыкны табып булырлык: кара, кызыл уылдык, сёмга, палтус, укбаш, чөгә, сөләйман, җәен кебек балыклар, төрледәнтөрле салатлар дисеңме, кайнар ризыклар берсен берсе алыштырып тора.* Т.Галиуллин

**УКБОРЫН** *и. зоол. к.* **укбаш**. *Анда һәр ел саен биш миллион чамасы яхшы токымлы балыклар: укборын, чөгә, кырпы үрчетелә.* М.Зарипов

**УК-ҖӘЯ** *җый. и.* Ук һәм җәядән гыйбарәт гади сугыш кораллары комплекты. *Хәзер антик чор түгел, укҗәяләр музейларда гына.* Н.Шәрифуллин. *Миңа кылычтан да, ук-җәядән дә, сөңгедән дә көчлерәк корал кирәк.* Н.Фәттах

**УК-ҖӘЯЛЕ** *с.* Ук һәм җәя белән коралланган. *Мин җәяүле идем. Укҗәяле идем, Ут-ядрәләр алмас Сүзләр барын белдем.* Л.Шагыйрьҗан

**УКЛАД** *и. рус* Нинди дә булса иҗтимагый-икътисади формациянең урнашкан, җайга салынган иҗтимагый хуҗалык итү формасы. *Милләтнең тормыш уклады сакланмаса, милләтне дә саклап калу мөмкин түгел.* З.Хәким. *Милли гадәтләр, традицияләр, халыкның көнкүреш укладı, социаль шартлар белән бергә, һичшиксез, халыкның җирле табигать үзенчәлекләре һәм аның географик даирәсе белән бәйле.* К.Гыйззәтов

**УКЛА́У** *и.* 1) Камыр җәя торган шома түгәрәк таяк. *Аннан соң майлы камыр яса, уклау белән җәй, бер табага сал.* К.Насыйри. *Теләсә, хатын-кыз тәртәдән дуга бөгә, дугадан уклау ясый ала.* А.Гыйләҗев

2) *махс.* Төрле механизмнарда хәрәкәтне үзе белән бәйле детальләргә тапшыра торган әйләнмә кендек, таяк. *Алгы цехта юан корыч уклау Калай җәя кызыл тимердән.* Х.Туфан

3) Сабанның аерым өлешләре беркетелә торган борыс; *русчасы:* **грядиль**

4) *диал.* Такта түбәләрдә һәрьяклап, салам түбәләрдә козырёк янында катлап кагыла торган такта

◊ **Уклау йоткан** Төз гәүдәле, иелергә кирәк чакта да иелми, бөгелми, туптуры торган кеше турында. *Каравылчылар гына уклау йоткандай басып калды.* З.Мәхмүди. *Комсомолның район комитетыннан вәкил булып, уклау йоткандай турыга каткан бер егет килгән, чырае бик караңгы.* М.Маликова

**УКЛАУЛАП** *рәв.* Уклау формасына кертеп, озынча йомры төргәк итеп төреп. *Сөләйман, хикәясен уклаулап төреп кулына тотып, редакциягә китте.* К.Тинчурин

**УКЛЫ** *с.* 1) Угы яки уклары булган. *Кылычлы, уклы ирләрдән соң изге түгәрәккә сөңгечеләр килеп керде.* Н.Фәттах. *Үзегез илә көбә, калкан, уклы садак алырга вә күрше авылларның азамат ирләрен дәшәргә онытмагыз.* В.Имамов

2) Ук формасында булган; ук сурәте төшерелгән. *Кайбер төрләрнең яңадан ясалу, яңадан төрләнүләре уклы сызыклар белән күрсәтелде.* Г.Алпаров

3) Чаккычы, угы булган (бөҗәкләр тур.); кагылган вакытта яндыру, чагу органнары булган (үсемлекләр тур.). *Без барган бу сукмак буйлап күптән*

*йөрмиләр булса кирәк, аның кырыйларын тигәнәк һәм зәһәр уклы яшел кычыткан баскан, чамалабрак бармасаң, читкә тайпылсаң, алар язгы усал ата каз кебек каптырып-тешләп алалар.* Р.Сибат. *Уклы органнар*

4) *күч.* Чәнечкеле, зәһәр. *Газзәбануның нәфрәт тулы уклы күзләре көндәшенә текәлде.* Г.Галиева. *Уклы сүзең яралый да Сутлы сүзең дәвалый.* М.Галиев

**УКЛЫК** I *и.* Аркага асып яки билгә тагып йөртелә торган ук савыты, садак. *Ул Тотышның сөңгесен, көбәсен, калканын чыгарып җиргә куйды, аннары җәясен, уклыгын, иярен алып чыкты.* Н.Фәттах

**УКЛЫК** II *с.* **1.** Ук ясар өчен, шуңа яраклы, шуңа дигән. *Уклык каен*

**2.** *и. мәгъ.* Ук ясарга дигән материал. *Бер агачтан уклык та чыгар, сөңге саплык та чыгар.* Мәкаль. *Корыган чыршыны Уклыкка дип ярдым. Тезсмә салдым да Нәзек ук шомарттым.* Ш.Гаделша

**УКЛЫ́ КЕРПЕ** *и. зоол.* Җайра, дикобраз

**УКЛЫ́ ЧЕБЕН** *и. зоол.* Хортумчыгында төкчәләре булган, көзен чыгып әче тешли торган чебен; *русчасы:* **жигалка**. *Шөпшәләр, божаннар, уклы чебеннәр аркасында колхоз умартачылыгының түбәнгә тәгәрәвенә тагын бер дәлил.* К.Рәхим

**УКМАШ** *с.* **1.** Укмашкан, оешкан. *Кыркылмаган, тузгыган укмаш йонлы ятим дөя баласы сыман бер мәгънәсезгә ялгыз болыт йөзеп йөри.* Казан утлары. *Кәбестәнең укмаш чәчәкләрен аерып чыгабыз.* Шәһри Казан

**2.** *рәв. мәгъ.* Укмашкан хәлгә килеп; бергәләп, төркем булып, укмашып. *Укмаш яшәү*

**УКМАШКА** *и. диал.* Аерым кисәкләрне, аерым әйберләрне укмаштырып, беркетеп ясалган нәрсә. *Рәшәткә баганасы рәвешлерәк дүрткел кирпеч укмашкасы өстенә куелган калай савытта артык төтәмичә генә ак парафин яна иде.* Ш.Маннур

**УКМАШТЫРУ** *ф.* 1) Таралучан, сибелүчән нәрсәләрдән бербөтен барлыкка китерү; укмаш хәлгә китерү, тоташ итү. *Ике яктан тезелеп киткән бертөсле ишекләр турыннан узганда, Давыт ирексездән чыраен сытты: пычкы чүбеннән укмаштырылган бу ишекләрнең өсте фанер булып, аңа, имән тактага охшатып, майлы буяу сыланган иде.* М.Маликова. *Эченә сыер йонын укмаштырып тегелгән безнең туп үтә йомшак булганга, ерак очмый.* Н.Сәфәрев

2) *күч.* Кемне яки нәрсәне дә булса бергә оештыру, туплау, төркемләү, бергә кушу. *Бу шайканы укмаштырып монда алып килүче минем иң якын дустым килеп керде.* М.Вәлиев. *Язмыш дигәнең, булачак парларны укмаштырганда, «бер яхшыга – бер яман, бер яманга – бер яхшы» дип бүлә икән, дигән мәзәк бар бит.* М.Маликова

3) *күч.* Тегеннән-моннан җыйнаштыру, аннан-моннан гына кысасына кертү. *Шәкертләргә нәрсә – аларга кызык кына: беренче эш итеп тактатоктадан укмаштырган гомуми кухнядагы керосинка һәм примус кебек нәрсәләрне тәрәзәдән атканнар, аннары хан заманыннан калган тимер караватларга барып тотынганнар.* А.Тимергалин. *Күршебез – балта остасы Әнвәр абый, колхоз эшеннән бушаган арада, иске өйнең калдык-постыкларыннан мал өе укмаштырып бирде.* Ватаным Татарстан

4) *күч.* Сугып җибәрү, салып җибәрү, ману. *Ияк астына берне укмаштырган идем, мәтәлеп-мәтәлеп китте.* А.Расих

**Укмаштыра башлау** Укмаштырырга тотыну. *Алары белән дә танышып чыккач, җәй көне комга язып өйрәнгән хәрефләр буенча сүзләр укмаштыра башладым.* Ш.Маннур

**Укмаштыра төшү** Бераз гына укмаштыру; тагын укмаштыру

**Укмаштырып бетерү** Тәмам укмаштыру. *«Бу халыкны җитмеш ел буе бутадылар-бутадылар, камыр урынына изделәр-бастылар, әмма барыбер бер иш итеп укмаштырып бетерә алмадылар», – дип уйлады Харис.* М.Маликова

**Укмаштырып карау** Сынау максаты белән укмаштыру. *Хәзер алты туганны бергә укмаштырып кара әле син...* Р.Вәлиев

**Укмаштырып кую** Тиз арада укмаштыру; алдан ук укмаштыру. *Алар яңадан эшкә киткәч, Зоя Кузьманың Таняга карата таралып бара торган шиген яңадан укмаштырып куйган.* Ш.Бикчурин

**Укмаштырып тору** Гел, һәрвакыт укмаштыру. *Ни өчен гаиләләр еш таркала – димәк, аларны уртак кан бәйләп, укмаштырып тотмый.* Т.Галиуллин

**Укмаштырып яту** *сөйл.* Укмаштыру процессында булу. *Инде мин килгәндә үк сүтелгән иске мәчет бүрәнәләреннән клуб укмаштырып яталар иде.* Ш.Маннур

**УКМАШТЫРЫЛУ** *ф. төш. юн. к.* **укмаштыру**. *Җир читенә барып, нәкъ менә Казанның яңа районнарындагы кебек бертөсле шакмаклардан укмаштырылган типовой йортлар арасында йөрермен, дигән уй аның башына да килмәгән иде.* М.Маликова. *Ун минутлык юлны әллә кайлардан урый-урый кырык минут эчендә узгач, калдык-постык такталардан гына укмаштырылган ларёк янына килеп чыктылар.* Ю.Әминов

**УКМАШУ** *ф.* 1) Аерым-аерым булган нәрсәләр тоташып ябышу, оешу. *Ул анда үзенең шакшы, кан һәм балчык укмашкан йөзен генә күрде.* Ф.Яхин. *--- икенче көнне иртән аларны җирләр алдыннан, өлкән сержант Мальцев, эзләнә торгач, аның лепкәсеннән маңгаена төшәрәк чәч арасында шырпы сыярлык кына тишек, чәченә укмашкан кан бөртеге тапты.* М.Имамов

2) *күч.* Төрле өлешләрдән, төрле урыннан җыелып оешу, төзелү, берләшү. *Бу як кешеләре татар, башкорт, казак, үзбәк, монгол, остяк сүзләреннән укмашкан үзгә бер «тамыр шивә»дә сөйләшәләр икән.* Ш.Маннур

3) *күч.* Бер төркемгә берләшү, туплану, оешу. *Ил буенча җыйсаң, шактый зур банда булып укмаша алар.* Ә.Баян. *Кайбер урыс кенәзләре бергә укмашса да, ул, койрыгын да күрсәтмичә, елдам гаип була.* В.Имамов

4) *күч.* Бер урынга җыйналу, туплану, бер урында оешып тору. *Бергә укмашып орышу турындагы фәрманга буйсынмыйча, Пәри Рәис, үз белдеге белән Фарсы култыгын ташлап, бөтенләй кире якка – Һинд ярына киткән.* В.Имамов. *Чыннан да, уйсу чирәмлектә, укмашып, берничә кеше утыра иде.* А.Гыйләҗев

**Укмаша бару** Торган саен ныграк укмашу. *Бөтен киемгә кар укмаша бара, әйтерсең ак аюлар без хәзер...* Ш.Маннур

**Укмаша башлау** Укмашырга тотыну. *Җәй көне сарык йоны, әгәр пычранып бер-берсенә ябышса, төерләнеп укмаша башлый.* С.Поварисов

**Укмаша төшү** Бераз укмашу; тагын укмашу. *Хәтергә шул уелып калган: юрган, күрәсең, сарык йонынннан ясалган булып, кайбер урыннары укмаша төшкәнгә, яктылык күренгәндер.* Ә.Баян

**Укмашып бетү** Тәмам укмашу. *Карасак: каен төбенең тирән куышында, берсенә берсе уралып, тубал хәтле йомгак булып укмашып беткән исәпсез-сансыз кара елан кайнаша!* Г.Бәширов

**Укмашып калу** Ниндидер тәэсирдән соң укмашкан хәлгә керү. *Бөтен тәне, бөтен әгъзалары белән бөрешеп, ул бер йодрыкка укмашып калды.* Н.Фәттах

**Укмашып килү** Соңгы арада укмаша башлау. *Ул соңгы елларда көчле бер йодрык булып укмашып килгән шагыйрәләребез иҗатының баш бармагы булды, дисәк, шәт, каршы килүче табылмастыр.* Р.Вәлиев

**Укмашып тору** Әледән-әле укмашу; укмашкан хәлдә булу. *Бер почмакта, тыгыз йодрык булып, офицерлар, сул эсерларның боевиклары укмашып тора.* А.Гыйләҗев

**УКМА́Ш-УКМАШ** *рәв.* **1.** Күпләп укмашып, күп итеп оешкан төерләр хасил итеп. *Җәнлекнең йоннары укмаш-укмаш тора*

**2.** *с. мәгъ.* Укмашкан, укмашкалар хасил иткән. *Укмаш-укмаш мамык*

**УКМА́ШЧӘЧӘКЛЕЛӘР** *и. бот. күпл. к.* **оешмачәчәклеләр**

**УКОЛ** *и. рус мед.* Тире астына, мускулга, венага махсус энә ярдәмендә дару җибәрү. *Янда торган өстәлдән шприц алып, күлмәк җиңе аша гына аңа ниндидер укол кадады.* К.Кара. *Кичен ул миңа ниндидер укол салды салуын.* З.Хөснияр

**УКРА** *и. зоол.* Имезүче хайваннарның тире астында паразит булып яшәүче кигәвен корты. *Кешегә авыз ачып икърар итмәсә дә, хәтта күз кабагы, кашы тартудан, күз кычытудан да тиктомалга пошынып, укра тешләгән сыер кебек, җанын-тәнен кая куярга белми гаҗиз булып йөргән чаклары байтак аның.* Б.Камалов. *Сыерлар ябык, янбаш сөякләренә чиләк эләрлек, сыртларын укра баскан, барысы да башларын салындырган.* М.Мәһдиев

◊ **Украсы котыру** Үз-үзен кулда тота алмау, тотнагы бетү, тезгенсезләнү; бете котыру. *Берәр начальник килсә, аның үзен күрсәтәсе килепме, яки тегенең ялгышын тотарга теләпме, украсы котыра торган гадәте бар.* Х.Камалов. *Чыннан да украң котырган синең бүген, Асыл.* Х.Хәйруллин

**УКРАИН** *и.* Телләре көнчыгыш славян төркеменә караган, күбесе православие динен тоткан, Украинада күпчелекне тәшкил иткән халык һәм шул халыкның бер кешесе. *Украин теле үзенең көйләп, сузып әйтелүе белән мишәрләрне хәтерләтә.* Г.Кутуй. *Бу илдә украиннар да, татарлар да, руслар да үз мәнфәгатьләренең ни рәвешле яклануын күрерләр.* Ф.Яхин

**УКРАИНАЛЫ** *и.* Украинада яшәүче кеше, Украина гражданы. *Ковёр күтәреп базардан чыгып барганда, ковёр сатучы ике украиналы апаның сөйләшүе колакка кереп калды: – Бу Украина түгел шул.* Н.Гариф. *Мәҗмуга битләрендә һәм төркестанлыларның, һәм украиналыларның, һәм кавказлыларның, һәм күп кенә башка халыкларның азатлык, бәйсезлек өчен көрәше эзлекле рәвештә яклана.* Х.Миңнегулов

**УКРА́ЙНЧА** *рәв.* **1.** 1) Украин телендә. *Фатыйма русча, украинча, белорусча җырлады, ниһаять, концертны алып баручы: – Татар халык көе «Шөгер», – диде.* Г.Әпсәләмов. *Телевидениенең күпчелек каналлары да украинча сөйләшә башлаганнар.* Д.Гыйсметдин

2) Украиннар кебек, шулар гадәтенчә. *Моңа тәмле итеп пешерелгән ит һәм балык шулпасы да, украинча пешерелгән борщ та һәм башка, һәм башка ит, балык, сөт ризыклары, төрле үләннәр, яшелчә-җимешләр сәбәп иде, әлбәттә.* К.Шәйхетдин. *Әле мин хезмәт иткән вакытта да алар украинча бииләр, чып-чын татарча такмак әйтәләр иде.* Ватаным Татарстан

**2.** *с. мәгъ.* Украин телендә булган. *Харьковта көн саен русча һәм украинча көндәлек сигез газета чыга.* Г.Кутуй. *Ял иткән араларда, күрәсең, аскы бүлмәләрдән русча һәм украинча җырлар ишетелә иде.* З.Нури

**3.** *и. мәгъ.* Украин теле. *Аның тамагына ниндидер кылчык кадалгандай булды, һәм ул, үзе дә сизмәстән, украинчага күчте.* А.Хәлим

**УКРА́ЙНЧАЛАП** *рәв.* Украин телендә. *– Трошки отдыхнём, дуже заморились, – диде ул, украинчалатып.* И.Гази

**УКРАЛАНУ** *ф.* Укра чыгу, укра басу

**Укралана башлау** Укралар барлыкка килү

**Украланып бетү** Тәмам укралану

**УКРАЛЫ** *с.* Укра баскан, украсы булган. *Былтыр да Әтнә базарыннан көя ашаган кәҗә тиресе илә укралы сыер тиресе җыеп кайткан иде.* Ш.Мөхәммәдев

**УКРОП** *и. рус бот.* Чатырчәчәкләләр семьялыгыннан туры сабаклы, каурыйсыман телмә яфраклы, тәмләткеч буларак кулланыла торган көчле исле берьеллык үләнчел үсемлек; шөет, турак уты. *Аш тәмле булсын өчен, ул шул әлеге тәмле ит өстенә тагын борычын, укробын өйдән алып барып сала.* Ф.Хөсни. *Аннан соң Фәридун абзый, үзе сайлап, яшел суган, укроп, петрушка, сарымсак кисә, җитешкән яңа яшелчәләрне үзе эзләп табып китерә, табынны да үзе хәстәрли.* В.Юныс

**УК СӨЯК** *и. анат.* Кошлар аягында бармакларына кадәр булган эче куыш сөяк

**У́КТАЙ** *рәв.* 1) Формасы, күренеше белән укны хәтерләтә торган. *Мин, аңа комачауламас өчен, читкәрәк киттем, уктай үскән тупылларга карап гаҗәпсендем: бер үк нәсел агачы ике җирдә ике төрле тормыш белән яши – кызык бу табигать дигәнең, җирдә үз кануны, үз карары...* Г.Гомәр. *Камыш гөле дә харап әрсез – уктай сабакларын чит туфракка атып тамыр җибәрергә аңа куш.* Д.Булатова

2) *күч.* Бик тиз, бик җитез, күз ачып йомганчы. *Адресны белүгә, Тәслимә уктай шундук атылыр төсле иде.* З.Хөснияр. *Куәтле җиңел машина асфальттан уктай очты.* К.Кара

**УКТАЛУ** *ф. диал.* 1) Талпыну, омтылу, ашкыну. *Күңел юкса һаман уктала...* И.Диндаров. *«Әллә ташлап китәргәме?» дип укталса да, серле җепләр белән бәйләнгән, ант сүзе белән үзен шушы адәмгә беркетеп куйганлыктан, бер карарга да килә алмады, бер ноктага текәлеп утыруын белде.* Ф.Латыйфи

2) Ташлану, ябырылу. *Сәхәп түш кесәсеннән алтын тәңкә чыгарды, аны, Хәлимнең борын төбенә туры китереп, ярсып, укталып килә башлады.* Г.Гыйльманов. *Император, конторага кагылмыйча, туры гаражга укталды, күңеле сиздә, ахрысы.* Р.Камал

**Уктала башлау** Укталырга тотыну. *Дилүс үзенә уктала башлаган Булатка автоматын төбәде: – Стоп!* Г.Гыйльманов

**Укталып алу** *к.* **укталып кую**. *Сюжет барышы дәвамында Мөсәгыйдә берничә мәртәбә сабыйны алдына утыртып сөяргә укталып ала.* М.Хуҗин

**Укталып карау** Берәр нәтиҗәгә килү максаты белән укталу. *Инде берничә мәртәбә арткарак калып, сындырып алырга укталып та карады, ләкин үзеннән алда барган Үтинең әледән-әле артка борылып каравы гына аны тыелып калырга мәҗбүр итте.* Н.Фәттах

**Укталып куюу** Кинәт укталу. *Радик нидер әйтергә дип укталып куйды, әмма эндәшмәде.* М.Кәбиров

**Укталып тору** Хәзер, сөйләү моментында укталу. *Ул инде баядан бирле нәрсәдер әйтергә укталып торды.* Н.Фәттах

**УКУ** I *ф.* 1) Хәрефләр яки башка язу билгеләре белән язылган яисә басылган нәрсәне күз белән күреп аңлау, эчтәлеге белән танышу яки тыңлаучылар өчен кычкырып әйтеп бару. *Аларга калын-калын китаплар укымыйча җавап та биреп булмый.* А.Хәлим

2) Язылган яки бастырылган ниндидер текстны таный белү, аңлый алу. *Аан Каалеп, теге яки бу дәрәҗәдә аңлап, кырыклап телдә укый икән.* Т.Әйди. *– Русча укыйсыңмы? – дип сорады ул, китапларның татарча булмавына куанып.* А.Гыйләҗев

3) Нинди дә булса билгеләрне белү, аңлау. *Сызымны укый-укый, Хәмзәнең күзе ватман кырыйларына төште.* Р.Хисмәтуллин. *Әнием матур итеп җырлый, кечкенә энем, әйбәт җырлавына өстәп, нотаны да укый иде.* М.Хуҗин

4) Нинди дә булса текстны күңелдән, яттан әйтү, сөйләү. *Ул чак кына тынып торды да, башын артка ташлап, «Ленин» поэмасыннан өзек укый башлады...* Г.Әпсәләмов. *Шунда ул үзенең һәм үзе яраткан безнең чор шагыйрьләренең (без фәкыйрегезнең дә) шигырьләрен яттан укып сокландырган иде.* Г.Бәйрәмова. *Ул миңа шигырьләр укый, яратуы хакында шундый матур итеп сөйли, мин үземне оҗмах бакчасында итеп сизә башлыйм.* Г.Тарханова

5) Язуга карап яки яттан ниндидер текстны көйләп сөйләү. *Ислам динендә әүвәл азан укыган кемсәнә – Билалдыр.* К.Насыйри. *Менә Коръән укыдылар, дога кылдык.* Г.Рәхим

6) Тыңлаучыларга телдән нинди дә булса мәгълүмат бирү, нәрсәнең дә булса эчтәлеген сөйләү. *Ул Куфә, Басра, Багдад шәһәрләрендә вәгазь укый һәм хокук мәсьәләләре буенча дискуссияләр алып бара.* А.Тимергалин. *Ничә көн буена лекция укый инде, иллә мәгәр елмаюны белми.* В.Имамов

7) Нинди дә булса белемне, һөнәрне үзләштерү, ниндидер һөнәргә өйрәнү. *Мин сине актёрлыкка укыйсың дип уйламадым да...* Г.Каюмов. *Армиядән кайткач, Булат юристлыкка укырга кермәкче иде: шуны уйлап, бик күп китап җыйды.* Г.Гыйльманов

8) Нинди дә булса уку йортының укучысы булу, белем алу. *Кыш көннәрендә, беренче баскыч мәктәптә укыган чакта, бер кабартма кисәге өчен, ул аның сыеры асларын карап кайта иде.* А.Алиш. *Кыз инде урта мәктәптән соң Казан университетына укырга кергән, бер курсны тәмамларга өлгергән икән.* Ж.Дәрзаман

9) Дога кылу, ниндидер хисләрне белдерү, өшкерү максаты белән ниндидер сүзләр әйтү. *Аяусыз хөкем чыгарды хатын, ләгънәт укыды, каргады...* А.Гыйләҗев. *Анда менгәч тә, әлеге әфсен-төфсенен укырга керештеме, кортлар шунда ук ничектер тынып калдылар, аның кулларына, кояшта янган таза беләкләренә утыра башладылар.* А.Хәсәнов

10) Билгеле текстны яттан әйтә бару белән бергә ниндидер тәгаенләнгән хәрәкәтләр ясау. *Ул, шкафны ачып, пар аккош төшкән зур сөлгесен, намаз укыганда кия торган киңчә күлмәген үреп алды, аннан ванна бүлмәсенә юнәлде.* А.Әхмәтгалиева

11) *күч.* Нинди дә булса тышкы билгеләргә карап, кичерешләрнең, вакыйгаларның һ.б. эчке мәгънәсен күреп сизү, аңлый алу. *Кошлар эзен укый күктән, Укый үлән ымын да.* Г.Морат. *Җөмләнең сүзен сүзгә ялгап, ул гүя Язилә ишетергә теләгән җавапны Әмирнең күзләреннән укып әйтте.* К.Кәримов

**Укый бару** Рәттән, эзлекле рәвештә уку. *Укый барам, укыган саен соклануым арта бара.* Г.Бәйрәмова

**Укый башлау** Укырга тотыну. *Бу авылда безнең Кәмәли абзый белән Әсхәпҗамалттәй дигән якыннарыбыз бар икән. Шуларда торып укый башладым.* Ш.Маннур

**Укып алу** Бераз гына уку. *Әхмәт Хөсәенов кадими мәдрәсәдә бераз укып алган булса да, уку-язуны үзләштерә алмаган һәм соңыннан, халыкның фәкыйрьлегенә, наданлыгына белемсезлек гаепле, дип санаган.* А.Тимергалин

**Укып бару** *к.* **укый бару**. *Ул елларда татар телендә чыккан барлык газета-журналларны укып барган әти Сәгыйть Сүнчәләйнең Габдулла Тукай, Мәҗит Гафурилар шикелле ук шигырь язуын яхшы белә иде.* Р.Ишморат

**Укып бетерү** Укуны тәмамлау; укуны төгәлләү, укуны туктату. *Укып бетергәч, заводны ташлыйсыңмы?* А.Гыйләҗев. *Ләкин беренче җөмләне укып бетергәнне дә көтмәде тегеләр, икесе тиң кычкырып көләп җибәрделәр.* В.Нуруллин

**Укып бирү** Кемгә дә булса нәрсәнедер уку. *Минем сүзләремә ышанмасаң, мадьяр илчеләрен чакырт та, шулар укып бирсен.* В.Имамов

**Укып җибәрү** Укырга керешү. *Ашап туя да амин тотып көйләп укып җибәрә, олылар да шаккатып тыңлый үзен.* А.Әхмәтгалиева

**Укып йөрү** Уку процессында булу; еш һәм күп урыннарда уку. *Бала чагында беренче классларда ук ятланган бу шигырь безгә бик аңлашыла, һәм без аны һәркайчан, һәр җирдә кычкырып укып йөри идек.* Р.Ишморат

**Укып калу** Укырга өлгерү. *Гарәп әлифбасы белән укып калган булсак, алар безнең җанга-аңга үтеп кердә алмаячак иде.* В.Имамов

**Укып карау** Укырга тырышу. *Хәрефләрне берәм-берәм укмаштырып укып та карыйм – һич дөрес язмаган!* Ш.Маннур

**Укып килү** Күптәннән уку; эзлекле укуын хәзергәчә дәвам итү. *Ул да минем шикелле белгәннәрен укып килә булса кирәк: иреннәре туктаусыз кыймылдый, ә үзе, изгеләрчә мөкиббән китеп, күзләрен үк йомган иде.* В.Нуруллин

**Укып китү** Укый башлау; туктаганнан соң укуны дәвам итү; ниндидер эш уңаеннан, шуның белән бер вакытта уку. *Укып китеп кеше булса, ул беренче бүләге итеп Алмабикә апаена чуклы шәльяулык алып бирәчәк.* А.Хәлим. *Тактаның бер ягын укып бетергәч, ул аны әйләндереп тота да, инде өстән аска таба укып китә.* А.Тимергалин

**Укып кую** Тиз генә, кыска гына вакыт эчендә уку. *Аннары берәр ырымлы әфсен булса да укып куярга уйлады.* Г.Гыйльманов. *Шуннан соң ашыга-ашыга уйларын кәгазьгә төшерә. Мыр-мыр итеп кенә укып куя.* З.Хәким

**Укып тору** Әледән-әле уку; һәрвакыт уку; хәзер, сөйләү моментында уку. *Башына ак кәләпүш кигән озын гына буйлы бер шәкерт тә шушы ук мәкаләне укып торган икән.* А.Тимергалин. *Азык-төлек программасы дип тукыганнарын да укып торабыз.* В.Имамов

**Укып узу** Узышлый уку. *Зиратның ком сибелгән аллеяларыннан атлаганда, агач яки тимер рәшәткә белән киртәләнмәгән кабер өсләрендәге ташларны, җиргә кырын яткырылган мәрмәр такталарны карап, алардагы язуларны укып узабыз.* Т.Әйди

**Укып үтү** *к.* **укып узу**. *Бу остазның югарыда без укып үткән сүзләре бүген бөтен кешелек дөньясы өчен дә үтә мөһим.* М.Вәли-Барҗылы

**Укып чыгу** Башыннан ахырына кадәр уку. *Шатлыгым эчемә сыймагач, шушы шигырьне бала чактагыча итеп укып чыктым.* Ш.Маннур

**УКУ** II *и.* 1) Хәрефләр яки башка язу билгеләре белән язылган яисә басылган нәрсәне күз белән күреп аңлау яки тыңлаучылар өчен кычкырып әйтеп бару эше. *Бу арада нинди китаплар укуын әйтеп алды.* М.Вәлиев

2) Белем алу эше, процессы. *Таймас курчак театры эшләренә кереп батты, чөнки Мәмәт ага беренче пьесаны төгәлләгән, Сәрия дә: «Уку елы башланганчы, бөтенесен әзерләп бетерик», – дип ашыктыра иде.* А.Тимергалин. *Иң кыены шул: эшче була торып, сменадан сменага эшкә чабып, арып-талып көч түккәннән соң, ничек институтта укуны башлап җибәрергә мөмкин?* Ф.Яхин

**УКУ́ ЙОРТЫ** *и.* 1) Белем бирү, укыту учреждениесе. *Татарларда элек-электән һәм бигрәк тә 1905 ел революциясеннән соң Европа, Шәрык илләренең уку йортларында белем алу табигый хәл санала иде.* М.Юныс. *Ул гадәт тә, холык та түгел, аңа югары уку йортларында да өйрәтмиләр.* Н.Гыйматдинова

2) *к.* **уку өе**. *Фәхрислам үзе көтү көтте, кичләрен уку йортына йөрде.* М.Мәһдиев

**УКУ́ ӨЕ** *и.* Совет чорында авылда культура-агарту учреждениесе. *Тиздән бүлмә бушап, иркенәеп китте, тавышлар тына төште, һәм уку өендә бары спектакльгә катнашучылар гына торып калды.* Н.Фәттах. *Кичен кабат уку өенә җыйналдык.* Л.Гыймадиева

**УКУ́-УКЫТУ** *җый. и.* Белем бирү системасы. *Балалар өчен уңышлырак әсәрләр язылса, алар уңышсызракларын кысрыклау һәм уку-укыту программасын тулыландыру рәвешендә дәреслек-хрестоматияләрнең яңа басмаларына кертелә иде.* Ә.Нигъмәтуллин. *Республикабызга, уку-укыту системасына басым елдан-ел көчәя бара.* Безнең гәҗит

**УКУЧЫ** *и.* 1) Уку белән шөгыльләнүче кеше; тыңлаучылар өчен яттан яки язылганга карап укыган кеше; кари; *русчасы:* **чтец**. *Шушы көннәрдә Кукмара мәдрәсәсендә Коръән укучылар бәйгесе үткәрелгән.* Безнең гәҗит

2) Мәктәп һәм урта махсус уку йортында укый торган бала яки үсмер; *русчасы:* **ученик**. *Мин, инде икенче сыйныф укучысы, ул кичәдә җиденче сыйныфларның уку китабыннан укытучым сайлап биргән йөз сиксән куплет Кызыл Армияне мактаган «үлемсез» халык җырларын яттан укыдым.* А.Хәлим. *Үзләре дә мәктәп укучыларына мөрәҗәгать белән чыктылар бернич мәртәбә.* Р.Мөхәммәдиев

3) Кемнәндер нинди дә булса белгечлеккә, һөнәргә, гыйлемгә өйрәнүче; өйрәнчек, шәкерт. *Ә Рәшит абый үзе «Мең дә бер комбинация» исемле китап язарга әзерләнә иде. Бу хакта аның укучысы – өйрәнчеге Яков Дамский да Мәскәүдә чыккан «Рәшит Нәҗметдинов» дигән китабында искәртә.* М.Хуҗин. *Хәбиб остазны күтәрү безнең буынга – аның укучыларына тия.* Н.Гыйматдинова

4) Әсәр, текст адресланган кеше, ниндидер әсәрне укыган кеше; *русчасы:* **читатель**. *Ә укучым сүзнең кем хакында барачагын алдан ук шәйләп алды инде.* Г.Гомәр. *Аптырама, хөрмәтле укучым, язуда бернинди дә ялгышлык юк – укытучының исеме нәкъ шулай.* Г.Шәйхи

5) Китапханәгә, уку залына йөрүче; *русчасы:* **читатель**. *Документлар, мәкалә, китапханә укучысы билеты белән портфелегезне дә тотып бәргәнсез.* Ә.Мушинский. *Төрле китапханәләр белән бәйләнешкә керә торган абонемент укучыга теләсә кайсы китапны табып бирергә булыша.* Сөембикә

**УКУЧЫЛЫК** *и.* Укучы булу. *Ул, башка яшь язучылар кебек, укучылык, өйрәнчеклек чорын бөтенләй диярлек кичермәде.* Р.Вәлиев

**УКУ́-ЯЗУ** *җый. и.* 1) Уку һәм язу эше. *Яучы хатыннар, үзләре димли торган кызларның уңганлыгын, кулы эш белүен мактап сөйләгәндә: «Уку-язуга да бик оста, теләсә нинди китапны су кук эчә», – дип тә ычкындыралар иде.* Г.Бәширов. *Вәрия – әнисенең тыңлаулы кызы – гөлбәч бүлмәдә табак-савыт тирәсендә маташа, Зәрия әтисенең электән калган уку-язу әсбапларын барлап азаплана.* К.Булатова

2) Укый һәм яза белү, грамота, сәвәт. *Ул [шәкерт] үзенең уку-язуы белән мактаныбрак [сөйләште].* К.Тинчурин. *Нигә соң мәдәнияттә, гыйлемдә иң алдагы америкалылар, европалылар үзләренең сөекле балаларына уку-язуны тиз өйрәтергә ашыкмыйлар?* Г.Алпаров

**УКЧЫ** *и.* 1) Ук ясап сатучы кеше, ук остасы

2) *тар.* Ук-җәя белән коралланган сугышчы; ук ату остасы. *Торгытай бәк үзе ихахайлап көлде, ат көтүе сыман яман кешни-кешни, укчылары аңа кушылды.* В.Имамов. *Аның белән ике йөз урыс укчысы, өч йөз Касыйм татары.* Р.Зәйдулла

3) *спорт* Ук атуда ярышучы спортчы. *Чаңгы спортына игътибарны күбрәк җәлеп итү, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, район укучылары арасында иң көчле спортчылар һәм укчыларны ачыклау максатында --- Дөбьяз урта мәктәбе базасында ату --- буенча ярышлар уздырылды.* Биектау хәбәрләре

4) Пехота гаскәрендә башлыча индивидуаль ату кораллары белән коралланган хәрби хезмәткәр. *Шул чакта, кызыл латыш укчылары белән берлектә, күпчелеге татарлардан торган Инза дивизия сугышчылары окопларын ташламыйлар.* З.Зәйнуллин. *Анда һава укчы радистлар мәктәбендә укыдым.* Ф.Яруллин

5) *астр.* Кәҗәмөгез белән Чаян арасында урнашкан көньяк ярымшардагы зодиакаль йолдызлык. *Ай Укчыда чакта бавыр бик сизгер, шунлыктан күбрәк җиләк-җимеш ашау файдалы.* Мәдәни җомга // Йолдызнамәдәге уникe йолдызлыкның тугызынчысы (22 ноябрьдән 21 декабрьгә кадәр вакытны эченә ала) // Шул вакытта туган кеше. *Ул, әни шикелле, Укчы йолдызлыгында туган. Укчылар талантлы була бит.* Л.Мәхмүтова

**УКШУ** *ф.* Косар алдыннан күңел болгану һәм бер үк вакытта корсак мускуллары кысылу, еш-еш сулау, ирексездән йөту хәрәкәтләре ясалу белән характерлана торган халәт кичерү. *Үзе бертуктаусыз укшый, эчендәге җан бөртекләре, тизрәк якты дөньяга чыгаруны сорап, тибенә башладылар.* Г.Гыйльманов. *Рәүф, кулларын бутап, нидер әйтергә теләде, ләкин сүзен әйтә алмады: ул укшый иде.* Р.Батулла

**Укшый башлау** Укшырга тотыну. *Шулвакыт Роберт буыла-буыла ютәлләргә тотына, укшый башлый.* А.Тимергалин

**Укшый язу** Чак кына укшымый калу. *Өстәлдәге эчемлек чәркәләрен күрүгә, кыз укшый язды.* З.Хөсняр

**Укшып алу** Аз гына укшу. *Барысы да үткән шикелле булгач, Михаилны урынга илтеп яткырды да үзе идәнне җыештырырга тотынды. Берничә тапкыр укшып алды.* М.Кәбиров

**Укшып җибәрү** *к.* **укшый башлау**. *Күзем төште дә чиле-пешле чебигә, күз алдыма үлгән чеби килеп, чак кына укшып җибәрмәдем.* М.Хәбибуллин

**Укшып кую** Бер тапкыр укшу. *Гөлҗиһан шулай диде дә тагы укшып куйды.* Ф.Бәйрәмова

**Укшып тору** Хәзер, сөйләшү моментында укшу. *Мөбарәк өйгә керде һәм хатынының юынгыч астындагы чиләккә укшып торуын күрде.* М.Шаһимәрдән

**УКШЫТКЫЧ** *с.* **1.** Укшыта торган, күңел болгануга китерә торган. *Чәче, сакаллары сазлык төбеннән тартып чыгаргандай укшыткыч һәм пычрак.* В.Имамов. *Анда җитәргә йөз адымнар кала, борынга укшыткыч ис килеп бәрелде.* Фирд.Хуҗин

**2.** *и. мәгъ.* Махсус рәвештә укшыта, костыра торган дару

**УКШЫТУ** *ф. з-сыз.* Косасы килүдән еш-еш сулату, корсак мускуллары кысылу һ.б. *Беренче кичләрне мине укшытып аптыратты.* А.Хәсәнов. *Укшыта, ачлыктан кабыргаларга ябышкан эчләр суырыла.* В.Гали

**Укшыта башлау** Укшытырга тотыну. *Карттан курыкканга шулай булгандырмы, аракы эчкәннекеме: мине шулчак бик нык укшыта башлады.* В.Нуруллин

**Укшыта язу** Чак кына укшытмый калу. *Бу төтен сулыш алганда укшыта язып үпкәгә кереп тула да, шулай ук укшыта язып кире чыга...* Г.Гыйльманов

**Укшытып бетерү** Тәмам укшыту. *Шүрәледәй җирәнгеч кыяфәте белән генә дә казанлыларны укшытып бетергән һәм яклаусыз калган Шаһгали «хан» янә, биштәр-төенчекләрен дә җыярга өлгермичә, Мәскәү тарафына чыгып качты.* В.Имамов

**Укшытып җибәрү** Укшытырга тотыну. *Борынына абзасының авызыннан шәраб, сарымсак исе килеп бәрелде, аны укшытып җибәрде.* Ф.Латыйфи

**Укшытып тору** Озак вакыт яки хәзер, әле укшыту. *Бозылган мәет исе ай буе исәннәрне укшытып торды...* Р.Габделхакова

**У́КЪЕЛАН** *и. зоол.* Тузбашчалар семьялыгыннан башлыча Урта Азия комлыкларында тереклек итә торган кечерәк агулы елан. *Укъелан кәлтәләр белән туклана*

**УКЪЯФРАК** *и. бот.* Көтүче кубызычалар семьялыгыннан сулык ярларында, сазлыкта үсә, ак чәчәк ата, өч аерчалы яфрагы ук башагын хәтерләтә торган үлән үсемлек; *русчасы:* **стрелолист**. *Җир астында укъяфракның тамырчалары була. Шул тамырчаларның очларында чикләвек зурлыгы гына бүлбеләр барлыкка килә.* Робинзон эзләреннән

**УКЫГАН** *с.* Укымышлы, белемле; белем алган. *Укыган кызмы соң ул?* Г.Камал. *[Заһит:] Дөрес әйтә. Арслан күбрәк белә шул, укыган кеше.* Ә.Баян

**УКЫЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **уку**. *Кеше күзеннән яшерелеп укылган шул төнге дога мине гаҗәеп бер ачышка китерде.* Ф.Хөсни. *Тора-бара Вәлидән «килгән» хатларга мин газеталардан укылган хәбәрләрне, кызыклы вакыйгаларны алып, аларны хатлар итеп балаларга тәрбия бирерлек рухта язарга өйрәндем.* Г.Кутуй

2) Укый алырлык булу, укый алу мөмкинлеге булу. *Кабер ташларының күбесе яхшы укылмый: вакыт, табигать үзенекен эшләгән.* Р.Галләмов. *Әгәр машинадагы теркәү номеры укылмаса яки ул бөтенләй булмаса, 500 дән алып 5 мең сумга кадәр штраф түләргә яки җәяү йөрергә туры киләчәк.* Ватаным Татарстан

3) *күч.* Нинди дер тышкы билгеләрдән күренү, аерылып тору, аңлашылу. *Ул вакыт Хикмәтулланың йөзендә, бу ниткән гаҗәеп сүз сөйлисең син, хаҗи, дигән сүзләр укыладыр иде.* Г.Камал. *Бу кичә дә халыкта әлегә хәтле һич күрелмәгән бер рух күтәренкелеге, һәммә кешенең йөзеннән укылып торган шатлык, һәрнәрсәгә хакыйкый бер бәйрәм төсе бирде.* Г.Исхакый

**Укыла башлау** Укылырга тотыну. *Капиталь ремонттан соң мәчеткә Мәскәүдән зур өч кәндил кайтартылып түшәмгә эләләр, вәгазьләр микрофон ярдәмендә укыла башлый.* А.Тимергалин

**Укыла килү** Күптәннән эзлекле рәвештә укылу. *Бу китап безнең халык арасында XVIII гасырда ук укыла килгән һәм кирәге зур булган.* Гали Рәхим

**Укылып бару** Рәттән, тоташ укылу. *Гомумән, «Татарстан яшьләре»ндәге һәр мәкалә 100 процент укылып бара.* Г.Нәҗметдинова

**Укылып бетү** Укылу эше төгәлләнү. *Әмма, кызганычка каршы, минем китап алар өчен, чынлап та, укылып бетмәгән соңгы китап булып калды.* Ә.Еники

**Укылып килү** *к.* **укыла килү**. *1990 елда мин үзем дә, халкыбызның элекләрдән укылып килгән китапларын барлау һәм җыйнау өчен, СССР Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтыннан бу якларга командировкага җибәрелгән идем.* Ф.Яхин

**Укылып тору** Һәрвакыт, әледән-әле укылу; хәзер укылу. *Ә Галимҗан Ибраһимовның исеме күңелдә һич искерми, әсәрләре гел укылып тора.* Кызыл таң

**Укылып чыгу** Башыннан ахырына кадәр укылу. *Хәер, сиксәненче елларның урталарында ук әле галимнең татар халкының этносын һәм этнонимын, ягъни аның исемен һәм җисемен ачыклауга багышланган кулъязма китабы (ул елларда аны бастырып чыгару мөмкин булмаган бер эш иде), кулдан кулга күчеп, бөтен татар зыялыларын әйләнеп укылып чыкты.* Р.Рахмани

**УКЫЛУЧАН** *с. к.* **укылышлы**. *Гадәттә, повесть һәм романнарның баштагы 50–60 бите, ягъни әсәрдә катнашачак геройлар һәм сурәтләнәчәк тормыш белән укучыны таныштыруга багышланган бүлекләре, авыр укылучан була.* Ф.Миңнуллин. *Ә бит кыска шигырьләр тизрәк тә, күбрәк тә укылучан.* Р.Фазлыев

**УКЫЛЫШ** *и.* 1) Укылу рәвеше; укылу ысулы. *Инглиз сүзләренең язылышы белән укылышы арасында аерма зур булуын белә идем.* В.Нуруллин. *Гарәп имласын акрын укыйм, кайчакларда сүзнең дөрес укылышын белмим яки мәгънәсен аңламыйм.* Р.Батулла

2) Парламент тарафыннан закон проектын тикшерү формасы һәм шул закон проекты турында фикер алышуның билгеле бер стадиясе. *Ул закон икенче укылышта кабул ителде.* Д.Шәйхетдин. *Кодекс өченче укылышта кабул ителде инде, президент кул куйгач, ул гамәлгә керәчәк.* Р.Вәлиев

**УКЫЛЫШЛЫ** *с.* 1) Укыр өчен нинди дер билгеле сыйфатларга ия булган; укыла торган. *Тәүфикъ Әйди язмалары, тирән эчтәлекле булу белән бергә, җиңел укылышлы, мавыктыргыч булулары белән дә аерылып тора, шунлыктан алар, көндәлек матбугатта дөнья күргәч, күп укучыларда җанлы кызыксыну уятты.* А.Гыйләҗев. *Романның журнал варианты, әйтергә кирәк, авыр укылышлы иде.* Р.Рахман

2) Уку мөмкин булган, аңларлык, күренерлек

3) Күп һәм теләп укыла торган, укучылар арасында популяр булган. *Кайсы китапларның иң укылышлы, популяр икәнлеген белү дә кирәк бит.* Р.Вәлиев. *Гәзит-журналларның гомуми тиражы 100әр мең һәм берничә миллион данәгә җиткән заманда, без, журналистлар, сенсация артыннан чаптык, кызыклы, укылышлы материаллар бирергә тырыштык.* Г.Гомәр

**УКЫМЫШ** *и. иск.* Белем, мәгърифәт. *Таҗи абзый – кырыктан уза барган кеше, авылда семьясы бар, укымышы да юк...* Ш.Маннур. *Михнәт чигү бәндәне уйландыра, аз-маз укымышы бар кешеләрне күргән-белгәннәрен, үпкәхыялларын кәгазьгә төшерергә, хәтта шигырь язарга да этәрә.* Т.Әйди

**УКЫМЫШЛЫ** *с.* **1.** Укыган, белемле, мәгърифәтле; белем алган; белеме күп булган. *Тәхаветдиннәр, укымышлы нәсел буларак, китапларын да, мәктәп-мәдрәсәләрен дә дошман кулына бирмәгән.* А.Хәлим. – *Исмәгыйль, сездәй укымышлы замандашыбыз белән танышуыма мин бик шат, – диде Данәгөл ханым.* А.Хәсәнов

**2.** *и. мәгъ.* Белем алган кеше; гыйлем алу нәтиҗәсендә күпне белгән кеше. *Татар җирлегенә килеп кергәч, аерым укымышлылар ул китапларга үзләренең нәсел шәҗәрәләрен дә өстәп язган очраклар бар.* М.Әхмәтҗанов. *Галим абзыйны үзе кебек укымышлыга чутлаган була.* А.Вергазов

**УКЫНАКЛЫ** *с. төр. иск. к.* **укылышлы**. *Шул арада ул җитез укынаклы, тиз язылмалы, комбинацияле нәфис бер язуга әйләнгән.* Г.Алпаров

**УКЫНУ** *ф. кайт. юн.* Үзалдына теләкләр теләү, догалар кылу, әфсеннәр һ.б.ш. уку. *Тик нишләп ул зиратта укынмый, пар нарат төбендә укына икән?* Г.Бәширов. *«Көтелмәгән яктан бәла килеп, йортны сүтеп кенә ташламасыннар!» – дип үзалдына укына.* А.Гыйләҗев

**Укына башлау** Укынырга тотыну. – *Китегез моннан, – диде авыру әкрен генә, күзләрен йомды, нәрсәдер укына башлады. – Әлхәмделиллаһи...* Г.Әпсәләмов

**Укына бирү** Бернигә карамый һаман укыну. *Үзе дә, ни сәбәптәндер, яулык очы белән күзләрен сөртә, аңлашылмаган телдә нидер укына бирде.* Ә.Баян

**Укынып алу** Кыска гына, тиз генә укыну. *Карт ана, бу сүзләрне куәтләп, иреннәрен кыбырдатып укынып алды.* З.Мурсиев

**Укынып кую** Кыска гына укыну. *Сәкинә карчык та тәрәзәдән шул якка карый, көрсенә, тәүбә, тәүбә, дип, авыз эченнән укынып куя да, кулын кушырып, башын бер якка янтайта биреп, нидер уйлый.* Ә.Хәкимов

**Укынып тору** Әледән-әле, еш укыну; хәзер, сөйләү моментында укыну

**УКЫТТЫРУ** *ф. йокл. юн. к.* **укыту**. *Бу китапларны үз мәктәбендә һәм якыннарының мәктәбендә укыттыра башладылар.* Г.Исхакый. *Хан кызы кулына төшсә, оста егетнең шәехтән никах укыттыруы көн кебек ачык иде.* М.Хәбибуллин

**УКЫТУ** *ф.* 1) *йокл. юн. к.* **уку**. *Ул шул миңа әллә нинди китаплар укытырга теләде.* Г.Исхакый. *«Выты, Хабушымнан хат, сау-сәламәт. Берчегезгә сәлам әйткән», – дип, кайда үзе, кайда башкалардан укытып, сөенеп туя алмады.* И.Салахов

2) Дәрес бирү, сабак өйрәтү, укытучылык итү. *Мин бит сине математикадан укыттым.* Н.Акмал. *Тәҗрибәле, акыллы ир затының кайда да алгы сафта булачагына авыл мәктәбендә укытканда ук ышанды Фагыйлә.* Г.Исхакова

3) Укырга мөмкинлек биреп, матди яктан тәэмин итеп тору. *Ходай язса, сезне аталы балалардан ким итмәскә тырышырмын. Икегезне дә укытырмын...* Ә.Моталлапов. *Нияте изге: буй җитеп килгән Бикташны шәһәрдә укытып, киләчәктә яхшы эшкә урнаштыру.* М.Маликова

4) Нинди дә булса җәмәгатькә намазда имам булу. *Мин әйтәм: «Гаетне мин укытырмын, җомганы син укытырсың», – дим.* Р.Вәлиев

5) *күч.* Кемне дә булса берәр нинди хәлне, тиешсез эшләрне яңадан кабатламаслык итеп җәзалау, сабак бирү. *Малай [Камалига] усалрак кадап әйтте: – Өеңә кайткач күрерсең кемне ничек укытканың!* К.Нәҗми. *Ну, укытканнар икән үзеңне дә.* М.Мәһдиев

**Укыта бару** Булган берсен эзлекле рәвештә укыту. *Аларны Сибгат ага Хәкимгә укыта бара идем.* Марс Шабаев

**Укыта башлау** Укытырга тотыну. *Алдагы кышта безне тел-әдәбият дәресләреннән Фарук абзый Билалов укыта башлады.* Ш.Маннур

**Укыта бирү** Бернигә карамый һаман укыту. --- *мәктәпләрдә укулар бетеп тормады, ач балаларның килә алган кадәресен ач укытучылар һаман әкрен генә укыта бирделәр.* Ә.Еники. *Элеккечә үк институтта укыта бирәм.* Ф.Яхин

**Укыта тору** Хәзергә, нәрсәдер башланганчы, үзгәргәнче укыту. *Әмма яшьләргә, очрашканда, [әсәрләрен] укыта торды, фикерләре белән кызыксынды.* Р.Гаташ

**Укытып алу** Тиз генә укыту; бернигә кадәр, кыска гына вакыт укыту. *Туктале, төп нөсхәне тагын Хөршидәттәйдән укытып алыйк әле.* А.Тимергалин

**Укытып бетерү** Укыту эшен төгәлләү. *Айсинә дәресләрен көч-хәл белән укытып бетерде.* Н.Көбәш

**Укытып йөрү** Күптәннән, инде озак вакыт укыту. *Училище тәмамлап та менә дигән итеп укытып йөриләр бит әле.* В.Нуруллин

**Укытып калу** Укытырга өлгерү. *Бар, кызым, форсат барында укытып калыгыз.* Т.Гыйззәт

**Укытып карау** Сынау максаты белән укыту. *Безнең Ак мәчет мәхәлләсендә, укытып карап, имам сайлау – беренче вакыйга.* Г.Баруди. *Тукта әле, мин аны икенче юл берлә укытып карыйм әле.* Г.Исхакый

**Укытып килү** Күптәннән эзлекле рәвештә укыту. *Абыстай кызларны безгә кадәр инде байтак укытып килгән, ул вакытта әле парталар да булмаган.* Р.Әмирханов

**Укытып тору** Билгеле бер вакыт укыту. *Мин мөгаллим вакытта анда балалар укытып торган идем.* Ш.Камал. *Рәмзия апа институтны тәмамлаганчы, Сәләй ага Казан мәктәбендә укытып тора.* Р.Зарипов

**Укытып яту** *сөйл.* Озак вакыт дәвамында укыту; укыту процессында булу. *Рәхәтләнеп балалар укытып ятарбыз.* Р.Батулла. *Көннәр буе чиркәүдән кайтып керүне белмәде, куна-төнә шунда малай-шалайларны укытып ятты.* В.Имамов

**УКЫТУ́-АГАРТУ** *җый. и.* Белем, тәрбия бирү, мәдәният тарату эшләре. *Күрше авылларда да аларның нәсел җепләре укыту-агарту эшенә мөһим өлеш кертә.* Т.Галиуллин. *Нәкъ менә укучылар массасы булуы, халыкны укыту-агарту кирәклеген аңлау прогрессив интеллигенция вәкилләрендә татарларның вакытлы матбугатын*

*булдыру буенча махсус проектлар төзү теләге уятты.* Г.Сабирҗанов

**УКЫТУЧЫ** *и.* 1) Уку йортында белем бирүче, нинди дә булса фән алып баручы. *Сәүдәгәрләр, университет укытучылары, адвокат, врач, инженер һәм башка һөнәр ияләре – Гомәр Каплан өенә унбиш-егермеләп кеше җыйналган иде.* Т.Әйди. *Кемнеңдер йомшак кына чәчемнән сыйпавын тоеп күтәрелеп карасам, янымда татар теле укытучысы ап-ак чәчле Раушания апам тора.* Г.Әдһәм

2) Ниндидер өйрәтмәнең башында торучы, фәнни мәктәп яки ниндидер тәгълимат булдырган абруйлы зат; остаз. *Дәрдемәнднең остазлары, укытучылары турында сүз чыкканда, гадәттә Хәйям, Хафиз, Кол Гали, Сәгъди, Низами, Акмулла исемнәрен, рус шагыйрьләреннән Тютчев белән Фетны атыйбыз.* Т.Галиуллин

**УКЫТУЧЫЛЫК** *и.* 1) Укытучы булу. *Минем кыюсызлыгымның төп сәбәбе, бәлки, аның укытучылыгында да булмагандыр...* А.Гыйләҗев

2) Укытучы һөнәре, эше. *Гаязның әнисе Камәриянең нәселе йөзәрләгән еллар буе имамлык һәм укытучылык эше белән шөгыльләнгән гаилә иде.* Г.Исхакый. *Нәрсә буласын алдан сизенгән сыман, укытучылыгын ташлап, монда ул үз теләге белән керде.* Н.Фәттах

**УКЫТУЧЫЛЫ́К ИТҮ** *ф.* Укытучы (*1 мәгъ.*) булып эшләү. *Октябрь революциясеннән соң Гаяз Максудов Казан университетының физика-математика факультетында укытучылык итә һәм «физика-математика фәннәре доценты» дигән гыйльми исем ала.* М.Мәһдиев. *Ул, имеш, безнең мәктәпкә күчерелгәнгә кадәр Боламык авылында укытучылык иткән.* Ф.Яхин

**УКЫТЫЛУ** *ф. төш. юн. к.* **укыту**. *Мәктәпләрдә татарча укытылды, клублар ябылып тормады, театрлар уйныйлар иде.* Д.Каюмова. *Анда чит тел дә укытыла.* М.Мәһдиев

**УЛ** I *и.* 1) Үзенең ата-анасына карата ир бала; угыл. *Сәгъдәт апа үзенең улын таный алмады.* Г.Гыйльманов. *Хатынын бәхетле иткән ир дә, улы белән кызы өчен җанын ярып бирердәй әти дә әле ул.* Г.Галиева

2) **улым** *тарт. форм.* Өлкән кешенең яшь иргә, егеткә, малайга мөрәҗәгать итү сүзе. *«Телеңнән куан, улым!» – дигән икән аңа кайчандыр бер апа.* А.Тимергалин. *Инде булмас, тәртәләрне кирегә борырга кирәк, дип торганда, Минеямал апа: «Ни йомыш иде, улым?» – дип сорамасынмы!* А.Хәлим

3) *күч.* Ир затыннан булган яшь буын. *Без алмашка килдек – яңа буын, энеләрең, синең улларың.* С.Хәким. *Белмим, аны безнең улларыбыз да булдыра алыр микән.* Н.Яһудин

4) *күч.* Үз ишенә, үз даирәсенә хас сыйфатларга ия буларак ир кеше. *Безнең як халкы фронтка куркуны белмәс батыр улларын гына түгел, киерелеп бер кешнәп җибәрсә, фашистның котын ала, тартгә җиксәң, әллә нинди авыр пушкаларыңны, тягачларыңны да берүзе өстери торган айгырлар да --- бирде.* А.Хәсәнов. *Ул, татар улларына хас тыйнаклык белән, бары көрешмәкче генә булган иде.* Ә.Еники

**УЛ** II (аның, аңа, аны, аннан, анда) *зат а.* **1.** 1) Сөйләүче һәм тыңлаучыдан тыш әңгәмәдә катнашмаган затны яки атамыйча нинди дә булса әйберне белдерү өчен хезмәт итә. *Гел ул гына кешеләргә акыл өйрәтеп йөрмәсен әле.* Ф.Яруллин. *Ул мине үлеп ярата ич...* А.Вергазов

2) Сөйгән ярны, гыйшык тоткан кешене белдерү өчен кулланыла. *Күрде дә шундук аңлады: бу ул иде!*

**2.** *күрс. а. функ.* 1) Алда әйтелгән, телгә алынган затны һәм предметны белдерү өчен кулланыла. *Ул кеше – сезнең әтиегез һәм картәтиегез иде, балалар!* А.Хәлим. *Әллә сихере үк бар иде инде ул хатынның.* В.Нуруллин

2) *Әнә, менә* сүзләреннән соң килеп, сүз барган зат, әйбер яки күренешнең нәкъ шул зат, әйбер яки күренеш икәнен күрсәтә. *Менә ул әни калдырган язу.* А.Алиш. *Әнә ул зираттан кайтып килә.* А.Гыйләҗев

3) Урын һәм вакыт аралыгына ишарә итүне белдерү өчен хезмәт итә. *Ул арада алдагы халык кузгала башлады, һәм без үзебезчә сафка тезелгән булдык.* А.Тимергалин. *Ул урында буран аеручаык котыра.* Г.Гыйльманов

**3.** *кис. функ.* 1) Үзеннән алда килгән сүз белдергән мәгънәне көчәйтү өчен кулланыла. *Ә председатель хатыннары турында чәйнәүчеләр күп була ул.* В.Нуруллин. *Көз матур ул.* Г.Кутуй

2) Үзе бәйләнгән сүз алдыннан килеп, аның мәгънәсенә көчәйтү төсмере өсти. *Сакмар өстендә туплар ярыла... Ул балык, ул балык... Чиләк бир әле.* А.Гыйләҗев. *Ә менә әлеге конкурстан Мәскәү телевизоры күрсәткән туннарга шаклар катарлык, искитәрлек: ул бизәлеш, ул чигешләр, ул мехны эшкәртү нечкәлекләре!* Б.Рәхимова

3) Берәр нәрсәнең шәплеген, көчлеген аңлатканда яки әсәрләнеп, гаҗәпләнеп сөйләгәндә кулланыла. *Ул Истанбул дисәң, анда фисык-фәсад инде.* Г.Исхакый. *Туй ул туй инде, үтте дә китте.* В.Ильясов

**УЛАК** *и.* 1) Суны, сыек яки бөртекле нәрсәләрне агызу өчен чокырайтып ясалган озынча җайланма. *Җае чыкканда, су тегермәнемнең улагын зуррак ачып куйыйм әле.* Г.Гомәр. *Улаклардан, чылтырап, чишмә суы агып тора.* А.Хәсәнов

2) Агачтан чокып ясалган, гадәттә, терлеккә я кош-кортка болгатып азык бирү һәм су эчерү өчен кулланыла торган озынча савыт; тагарак, ялгаш, колаша. *Аннары, кетәккә тагын кире менеп, шул азыкны аларның улакларына салып чыга, кайгыртучан хуҗа шикелле, бу чакта ояларда утырган кайбер күгәрченнәрен кулы белән капшап-капшап карый, куначалары астын чистартып ала...* Ә.Мушинский. *[Ат] ычкынып киткән дә улакка болгатырга дип салып куйган суны барып эчкән.* М.Гали

3) Гадәттә, такталардан зур әрҗә яки б.ш. формада ясалган, терлеккә тупас азык бирер өчен кулланыла торган савыт. *Печәннәрен азбар эченә кертеп, ат улагына салды да кое төбенә килде.* Г.Ибраһимов. *Мондый чакта улактан, мин сиңа әйтим, башың әйләнердәй тәмле булып, әрем, сукыр кычыткан, бөтнек, каен җиләге исләре килә.* А.Хәсәнов

**УЛАКЛАНУ** *ф. к.* **колашалану**. *Менә, ичмасам, атлар дисәң дә атлар! Ботлары багана юанлыгында, сыртлары улакланып эчкә баткан.* Ф.Яруллин

**Улаклана башлау** Улаклану билгеләре күренү

**Улаклана төшү** Бераз улаклану

**Улакланып бетү** Тәмам улаклану

**Улакланып тору** Улакланган хәлдә булу. *Вознюкныкына караганда ямьсезрәк яңаклары аз гына эчкә батып, улакланып тора.* С.Шәрипов. *Безнең өй турысында юл да улакланып тора, нәкъ шул спортчыларның әллә нинди исемдәге шуу юллары шикелле.* Татарстан яшьләре

**УЛАКЛА́У** *ф. сир.* Нәрсәгәдер улак кую, улаклы итү. *Шәйхи бабай улаклаган бу чишмәдә – Аның тавышы.* Р.Фәйзуллин

**УЛАКЛЫ** *с.* Улагы булган. *Һәм егет, озын улаклы чишмә яныннан инде авыл башына җитәрәк шактый сөзәкләнгән ярдан күтәрелеп, ике яктан да тәбәнәк тотылган киртәле тыкрыкка керде.* М.Хуҗин. *Фәрит дус белән без шыгырдавык сиртмәле, зур улаклы кое янының узып, яланаяк тәпили бирдек.* М.Рафиков

**УЛАН** *и. рус<төрки тар. хәрби* XVIII–XIX гасырларда рус армиясендә җиңел кавалерия гаскәрие. *Ул авылда җан асраучы кешеләрнең күпчелеге патша хезмәтендә егерме биш ел гомерен уздырган, мылтык, кылыч тотып, кеше үтерүдән башка һөнәрне белмәгән һәм белергә дә теләмәгән, инде иллегә җитеп килгән картая башлаган солдатлар – гусарлар, уланнар, артиллеристлар көн күргән.* З.Зәйнуллин

**УЛА́У** *ф.* 1) Тоташ һәм сузынкы, ыңгырашуга охшаш тавыш чыгару (эт, бүре һ.б. хайваннар тур.). *Әйтерсең лә монда кешеләр түгел, нииндидер ерткычлар өере җыелган: алар үз корбаннарын көтеп улыйлар, талашалар, бер-берсен ботарларга гына торалар.* М.Галәү. *Бүреләр инде бер-берсен уздыра-уздыра улыйлар.* З.Мәхмүди

2) *сөйл. хуплм.* Кычкырып һәм сузып-сузып елау. *Малай шыңшыды. «Җитәр, улама!» – диде төсе танымаслык булып бозылган Наилә.* А.Гыйләҗев. *Бары тик теш арасыннан гына, нәфрәтләнеп: «Һай, йөзе кара булгыры, мәлгунь җан...» – диде дә, миңа кушылып, ихтыярсыз кычкырып елый ук башлады. Бу тавышка сискәнеп, ишегалдында чуалган әтием дә капкадан килеп чыкты. «Бу нинди гарасат, нигә улыйсыз?»* Г.Галиева

3) *сөйл. хуплм.* Җырлый белмичә җырларга маташу. *Нәҗип белән Наилә пәрмә-пәр ызгыштылар, тавышка балалар уянды, ачу китереп, җир селкетеп поездлар үтә торды, аскы катта, чыр-чу килеп, исерек хатыннар җыр улады.* А.Гыйләҗев

4) *күч.* Сузынкы һәм сызгыруга охшаш тавыш чыгару (җил, буран һ.б.ш. тур.). *Шуның өстенә, шомлы күңелне тагын да шомландырып, төн буе җил улады, буран котырды.* В.Нуруллин. *Тышта буран һаман улый.* М.Мәһдиев

5) *күч.* Тоташ бер шау чыгарып эшләү, гүелдәү, гүләү (машиналар, механизмнар тур.). *Самолёт улаганын ишетәсең киләме?* А.Гыйләҗев. *Кемгәдер дулаган кебек, машина моторы улый...* Р.Сибат

**Улап алу** Бер тапкыр, кыска гына улау. *Моның өчен, тулган айга карап, өч тапкыр улап алу җитә икән.* Г.Гыйльманов

**Улап җибәрү** Уларга керешү. *Минем кеше үтергәнем юк иде, бүген икене үтерәм, дип, егет куркыныч тавыш белән улап җибәрде.* Р.Сәгъди

**Улап йөрү** Озак вакыт улау. *Мәнә кем бүре булып улап йөргән алайса!* З.Мәхмүди

**Улап карау** Сынау максаты белән улау. *Танавын һавага күтәреп, бертуктаусыз улап та карады.* Р.Батулла

**Улап кую** Кыска гына, аз гына улау. *Яңа этапның килеп җиткәнлеген белдереп, сирена улап куйды, тимер капкалар, ыңгырашып, як-якка ачыла башлады.* И.Сираҗи

**Улап тору** Билгеле вакыт улау; хәзер, сөйләү моментында улау. *Кеше кайчак, шамакайдай, китә тәмам онтылып: бүре төсле улап тора, өреп куя эт булып.* З.Мансуров. *Аның якякларыннан, тышта һава тыныч булмаганда, җил улап тора.* К.Җәмит

**Улый башлау** Уларга тотыну. *Базар марҗасы кебек улый башлады...* А.Гыйләҗев. *Ишетәсезме, әнә тагын берсе калынрак тавыш белән улый башлады!* В.Нуруллин

**Улый бирү** Бернигә карамый улавын дәвам итү. *Сигез төрле улый бирә сигез бүре.* Л.Фәтхетдинова

**УЛАШУ** *ф. урт. юн. к.* **улау**. *Ишегалдында үле-мәле килеп этләр өрә башлады, әллә ничә урында берьюлы акырып еларга, улашырга тотындылар.* Г.Бәширов. *Бистә ягында янгын машиналары улашты.* Н.Гыйматдинова

**Улаша башлау** Улашырга тотыну. *Ә монда, корсакта, «ач бүреләр» йөрәк тамырларын тырнап улаша башладылар бугай инде.* Ф.Яхин

**Улашып алу** Кыска гына вакыт улашу. *Хуҗаларын сагынып шыңшып, кайчагында улашып алган этләрдән башка авылда һичкем юк.* Х.Исмәгыйлев

**У́Л-БУ** *и.* Көтелмәгән хәл, күңелсез ситуация. *Кызың Кәшифә өйдә ич синең, ул-бу булса, кәҗәгезне чыгармый калмас!* В.Нуруллин. *Ул-бу юктыр бит инде, Кадрия Зиннуровна?* В.Имамов

**УЛҖА** *и. монг. иск.* Сугыш вакытында җиңүче җиңелгән яктан тартып алган мөлкәт; сугыш табышы, ганимәт. *Кисмә-кисмә сары алтын Кисеп улҗа итәр ул; Кашыклап җыйган малыңны Чүмечләп чәчеп бетәр ул.* Дастан. *Урыслар чигенә башлагач, меңбашы Хәмитшәех җирдә аунап яткан ат һәм адәм үләксәләрен җыярга, тукышта кулга төшкән улҗаны барларга боерды.* З.Мәхмүди

**УЛЛА́У** *ф. сир.* Ир бала тудыру. *Ул уллаган, кыз кызлаган.* Әйтем

**УЛЛЫК** *с.* Ул хәле, ул булу. *Әгәр дә ул уллык бурычын намус белән үтәп тә чыкса, бу көн аның гомеренең иң нурлы, иң гүзәл бер көне булып калачак.* Г.Әпсәләмов. *Уллык хисенә караганда, анда хәзер гашыйк егет хисе көчлерәк иде.* Н.Фәттах

**УЛЛЫККА** *рәв.* Гаиләгә бала итеп, балалыкка. *Анда баласыз кешеләр, үзләренә уллыкка, кызлыкка алу өчен, бөтен дөньядан бала эзлиләр.* Ф.Ярулин. *Мәнә Кәлимулла абзаң белән Зөһрә апаң, туганлык хисе күрсәтеп, Тәлгать улыбызны үзләренә уллыкка сорыйлар.* З.Зәйнуллин

**УЛЛЫ́-КЫЗЛЫ** *с.* Улы да, кызы да булган, балалы. *Алзәйнәп белән Гафур яраткан кияү белән игелекле килен, уллы-кызлы әти-әни булдылар.* Р.Рахман. *Бер-бер артлы уллы-кызлы була Хәбибуллиннар.* Безнең гәҗит

**УЛЬТИМАТИВ** *с.* Ультиматум характерындагы; кискен, катгый. *Алар шушы килешүгә кул куярга тиешле республикаларга Татарстанның ультиматив позициядә булмавын, хәтта ничек тә булса, кайчан да булса аңа кушылачагын исбат итү өчен һәм, Татарстанга ияреп, башкалар да бу документны имзалаудан баш тартмасыннар дип курыкканга күрә, сөйләшүне шушы көнгә билгеләгәннәр булса кирәк.* И.Таһиров

**УЛЬТИМАТИЗМ** *и. рус сәяси* Россия империясе III чакырылыш Дәүләт Думасының депутатларына каршы Үзәк Комитетның социал-демократ эшчеләр партиясенә буйсынуын таләп иткән ультиматум кую карашында торган агым

**УЛЬТИМАТИСТ** *и. рус сәяси* Ультиматизм тарафдары

**УЛЬТИМА́ТУМ** *и. лат.* 1) *сәяси* Нинди дә булса дәүләтнең хөкүмәтенә яки хәрби җитәкчелегенә куелган, үтәлмәгән очракта дипломатик мөнәсәбәтләрне өзү, көч куллану һ.б. белән янаган катгый таләп. *Бөекбритания 1924 елның ноябрендә Мисыр хөкүмәтенә ультиматум куя: Суданнан бик тиз генә*

*Мисыр гаскәрләрен чыгаруны таләп итә.* Ә.Хәйруллин

2) Гомумән янаулы катгый таләп. *Ул бернинди ультиматум формасында булмасын, әмма кискен сүз – татар халкының язмышы өчен борчылып әйтелгән сүз булсын.* Т.Миңнуллин. *Көннәрдән бер көнне мин әтигә бик кискен төстә ультиматум белдердем.* А.Хәсәнов

**У́ЛЬТРА-** *лат.* Кушма сүзләрдә «чиктән тыш» яки «артык нык, үтә югары дәрәҗәдәге», яки «катгый, экстремистик» мәгънәләрендәге беренче компонент (мәс., *ультразаманча, ультрасул, ультрашәмәхә* һ.б.ш.). *Әмма үзләрен Русия патриотлары дип белдергән төрле ультрапатриотик төркемнәрнең дә позицияләре көчле.* И.Хуҗин

**УЛЬТРАКОНСЕРВАТИВ** *с.* Чиктән тыш консерватив

**УЛЬТРАКЫСКА** *с. физ.* Үтә кыска. *Ультракыска дулкыннарда Тыңлап ятам дөньяны.* Г.Морат

**УЛЬТРАМАРИН** *и. нем.* **1.** Ачык зәңгәр буяу. *Пигментлар ике төркемгә бүленә: органик (нигрозин, хризоидин һ.б.) һәм минераль (охра, сурик, мумия, ультрамарин һ.б.).* Төзү материаллары

**2.** *с. мәгъ.* Ачык зәңгәр төсле, күксел. *Ультрамарин төсле буяу алып, Мин ясадым сине, үземне...* Шәһри Казан

**УЛЬТРАМИЛЛӘТЧЕ** *и.* Радикаль милләтче. *Ләкин беренче елдагы бәйрәм үк инде аның ультрамилләтчеләр өчен икәнлеген исбатлады.* Безнең гәҗит

**УЛЬТРАТАВЫШ** *и. физ.* Гади колак белән ишетү мөмкин булмаган югары ешлыклы тавыш тирбәнешләре. *Лазер, ультратавыш, микрохирургия кораллары, полимерлар, синтетика файдаланып, яңа эзләнүләр башлап җибәрелә.* Т.Әйди

**УЛЬТРАШӘМӘХӘ** *с. махс.* Үтә кыска булганлыктан күзгә күренми торган (нурлар, яктылык һ.б.ш. тур.). *Мондый чак кызыну өчен әйбәт түгел түгелен, ультрашәмәхә нурлар аз була, ләкин башка бер эш юк...* А.Тимергалин. --- *кәгазьләргә бары тик ультрашәмәхә яктылыкта гына күренерлек ефәк җепнең дә шул ук структуралысы кушылган.* Р.Мирхәйдәров

**УМАРТА** *и.* 1) Бал кортларын асрау өчен махсус әрҗә яки эче куыш бүкән. *Такта умарталарны бер читкә өеп куйганнар, ятим калган казыклар, дүртәр-дүртәр тезелгән бичара солдатлар булып, шыраеп утыралар.* А.Гыйләҗев. *Дөрес, баштагы мәлдә ул, пенсия кенәгәсенә кимсенеп, акча түли алырдай бер оешмага тагын каравылчы булып урнашып караган иде – балавыздан ясалма умарта кәрәзләре эшләү заводына.* К.Кәримов

2) Шул әрҗәдә яки бүкән эчендә яшәүче бал кортлары. *Әйе, Рейманнарның өлкән буыны алма үстереп, умарта үрчетеп, нык, иркен йорт-җир корып гомер иткән.* Т.Әйди. *Ата-бабалар ул урманнарны төпләп бетергәннәр һәм шул җирләрдә иген чәчкәннәр, мал үрчеткәннәр, һөнәрчелек белән шөгыльләнгәннәр, ауга йөргәннәр, умарта асраганнар, сәүдә иткәннәр.* М.Кәбиров

3) *диал.* Бал корты. *Умарталар оча җырлап киң болында, Күбәләкләр оча чәчәк кочакларга...* Г.Сөнгати. *Ул исә, нидер исенә төшергәндәй, телефон трубкасын алды: – Алло, алло, үзәк даруханәме? Умарта чакканнан дару... әйе...* Н.Каштанов

◊ **Умарта оясы (корты, күче) кебек (төсле, шикелле)** Бик зур массаның тигез һәм өзлексез шау чыгарып ыгы-зыгы килүе турында. *Әй халык базарда, әй халык, умарта корты төсле гөҗләп тора.* Т.Гыйззәт. *Халыкның умарта күче шикелле кайнап торуына һәм андагы әйберләрнең күплегенә исем китеп, базарны ике рәт әйләндем.* В.Нуруллин. *Бөтен стеналары сурәтләр белән шыплап тулган заллар умарта оясы кебек мыжлап тора иде.* Г.Гыйльманов

**УМАРТА́ АЕРУ** *ф. махс.* Яңа күч ясап, ана корт янына җыелу һәм төп умартадан аерылып чыгу; бала аеру, корт аеру; *русчасы:* **роиться**. *Бал суырткан бабай белән әлеге малай шатланып йөриләр: – Умарта аера, – диләр.* А.Алиш. *Ул көнне берьюлы бернечә умарта аерды.* Ф.Яруллин

**УМАРТА́ АНАСЫ** *и. к.* **корт анасы**. *Яшьләребез дә, умарта анасына ияргән кебек, янында гына бөтерелеп йөриләр.* Т.Миңнуллин

**УМАРТА́ БАЗЫ** *и. махс. к.* **умарта өе**. *Кояш астындагы елга җир асты елгасы тарафыннан йотылды, сандугач кабер эчендә томаланып калды, кырпы балыгы умарта базына килеп эләкте дә капъйот бәндәләр һөҗүменә дучар булды.* Т.Әйди

**УМАРТА́ БАКЧАСЫ** *и. махс.* Умарталар урнаштырылган махсус урын; чүнник. *Байтимер аша төннәрен мари урманындагы үзенең умарта бакчасына узып йөргәндә килә иде аның башына мондый тәмле уйлар...* З.Хөснияр. *Бүген дә менә урманга да, колхозның умарта бакчасына да хуҗа түгел ул: бар белгәне – көрәк тә сәнәк, балта да пычкы.* Н.Гамбәр

**УМАРТА́ КОРТЫ** *и. к.* **бал корты**. *Ләкин алар, борчылган умарта кортлары шикелле, һаман аның тирәсендә әйләнәләр, бик каты чагалар.* Г.Әпсәләмов. *Күпләр сарык асрамый хәзер, умарта корты бетте, божан юк, төклетура үрчеми, дөнья тутырып чебен-черки калды.* А.Гыйләҗев

**УМАРТАЛЫК** *и.* Умарталар куелган урын; умартачылык хуҗалыгы. *Тауларга менәр идек, мин сезне, умарталыгыма алып менеп, бал белән сыйлар идем.* Г.Тарханова. *Командировкадан кайтып төшү белән, умарталыкка ашыктым.* А.Хәсәнов

**УМАРТА́ ӨЕ** *и. махс.* Кышын умарталар урнаштырыла торган махсус эшләнгән өй, бүлмә, баз һ.б.ш. *Мине умарта өенә керергә кыстады.* Фирд. Хуҗин. *Ерakта умартачы өе, лапасы, тавык кетәге, умарта өе күренә.* А.Гадел

**УМАРТАЧЫ** *и.* Умартачылык белән шөгыльләнүче. *Тәпәндәге балны умартачы Хуҗәвәли китереп бирде.* Г.Әпсәләмов. *Җигүле ат якынлашкач, Төлке Аю тапкан көмеш тәңкәне умартачы килә торган юлга ташлаган.* Г.Гыйльманов

**УМАРТАЧЫЛЫК** *и.* 1) Умартачы һөнәре; умартачы булу. *Авылга кайткач, нарат бүрәнәләрдән зур йорт салырмын, Мәчтүрә белән картлык көнендә генә булса да бәхетле көннәр кичерермен, алма бакчасы булдырырбыз, умартачылык белән шөгыльләнермен, дип хыялланган идем, юләр.* З.Мәхмүди. *Габдулла ага әле дә умартачылыгын ташламаган, бакчасында, күп булмаса да, балы үзләренә, балаларына, оныкларына җитәрлек күләмдә корт асрый.* Әлмәт таңнары

2) Авыл хуҗалыгының бал һәм балавыз алу, авыл хуҗалыгы культураларын серкәләндерү өчен бал кортларын үрчетү белән шөгыльләнә торган бер тармагы. *Кавказда умартачылыкны үстерү. Умартачылык өчен белгечләр әзерләү*

**УМАЧ** *и. махс.* 1) Су яки сөт кушып уылган оннан әзерләнгән ашамлык. *Саклап кына торган арыш оны да берике тапкыр умач уарга җитсә җитәр.* Г.Исхакый. *Борчак оны умачка яхшы була.* Г.Әпсәләмов

2) Шул уылган ашамлык салып пешерелгән шулпалы аш. *Ярый ла, син куе умач ашап үскән, синең көчең дә күп, ә без?* А.Гыйләҗев. *Балалар да өстәл тирәли утырып, берсеннән икенчесе көнләшеп, ярыша-ярыша, кысыр умач ашадылар, чамалап кына киселгән арыш ипекәен валчыгын да калдырмый ашап бетерә башладылар.* Д.Каюмова

**УМАЧЛЫК** *с.* **1.** Умач уарга җитәрлек, умачка дигән. *Арыш оны иде умачлык.* Г.Афзал. *Кешеләрне куркытып, йорт саен тентүләр ясап, хәтта өй тулы балаларының да соңгы умачлык оннарына кадәр алып чыгып киткән кеше ул.* Г.Галиева

**2.** *и. мәгъ.* Умач уарга җитәрлек, кирәкле, яраклы он. *Әнкәй белән сеңелкәшләргә ел әйләнәсенә җитәрлек умачлык та бирмәде бит.* Х.Хәйруллин

**У́МБРА** *и. лат.* Составына тимер яки марганец оксидлары кергән балчыктан ясала торган куе көрән минераль буяу. *Залның бизәлешендә җирне хәтерләтә торган төсләр (охра, умбра) кулланылган.* Фәнни Татарстан

**УМЛА́УТ** *и. нем. лингв.* 1) Кушымчадагы алгы рәт сузык тәэсирендә тамырдагы сузык авазның палатальләшү күренеше

2) Шушы күренешне белдерә торган диакритик билге (башлыча хәреф өстенә куела торган ике нокта). *Шулай итеп, 29 хәрефтән торган бүгенге төрек алфавитында 23 «саф» инглиз хәрефе, 2 умлаутлы (төрткеле) алман хәрефе һәм латин шәкелендәге 4 «төрек» хәрефе (икесе койрыклы, берсе дугалы, берсе ноктасыз).* И.Әмирхан. *Ә бит күчәр татарча гына шулай яңгырый, бүтән төрки телләрдә – көчәр (умлаутлы ö белән әйтелә).* Р.Әхмәтьянов

**УМЛЯ́УТ** *и. нем. лингв. к.* **умлаут**. *Ә ъ һәм ь клавиатурада артык урын биләп торганчы, сүзләрне юкка озынайтканчы (укырга өйрәнгән вакытта бу да әһәмиятле – кыска сүзне тизрәк өйрәнәсең) боларны берәр умляут ише әйбер белән генә алыштырып булмыймени?* Безнең гәҗит

**УМРА́У** *и. анат.* Калак сөяге белән күкрәк сөяген тоташтыра торган S формасындагы парлы сөякнең һәрберсе; *русчасы:* **ключица**. *Лёша, беребез дә көтмәгәндә, каты яраланды, коткарып калырлык түгел иде: ярчыклар муенын, кан тамырын, умрау сөяген, уң җилкәсен тишкәләгән, уң кулының бөтен бармакларын чәрдәкләгән иде.* Т.Кәримов. *Күкрәк мускуллары астында урнашкан умрау асты мускуллары канатларны күтәрә.* Биология

**УМЫ́Л УТЫ** *и. бот. к.* **еланбаш**

**УМЫРЗАЯ** *и. бот.* Нәркисчәләр семьялыгыннан үскән урынына бәйле рәвештә төрле төсләрдә (ак, зәңгәр h.б.) чәчәк ата торган, кыска сабаклы, күпьеллык, суганчалы үләнчел үсемлек; кар чәчәге, эргәзембай. *Бу үләннең чәчәге яз башында, кар китүгә үк чыга. Кайбер авылларда аны умырзая дип тә йөртәләр. Бездә «кимәшә башы» дип атыйлар.* А.Гыйләҗев. *Әнәс терелеп чыкканда, кояш турырак караган урыннарда беренче умырзаялар баш калкыткан иде инде.* Н.Әхмәдиев

**УМЫРТКА** *и. анат.* Умырткалыкның өлешләрен тәшкил итә торган аерым сөяк яки кимерчәк. *Астан иң соңгы умырткаларың янында нык кызарган ике урын бар.* Г.Галиева. *Муен һәм арка умырткалары сынган...* Марс Шабаев. *Анда кеше сыярлык кечкенә бүлемтекләргә, ягъни кабиналарга кереп утырасың да кораб мачтасы кебек шагыр-шогыр килә башлаган буыннарыңны, умыртка сөякләреңне кыздырасың.* А.Хәлим

**УМЫРТКА́ БАГАНАСЫ** *и.* 1) *анат. к.* **умырткалык**. *Бехтерев авыруыннан кеше кыймылдый алмый, тамагына үтми, умыртка баганасы бамбук сыман кибә, диелгән.* К.Кәримов. *Нурсөянең умыртка баганасы чатнады.* Н.Гыйматдинова

2) *күч.* Нәрсәнең дә булса иң төп нигезе, терәге. *«Безнең Вил – хуҗалыкның умыртка баганасы ул, – ди, – утсыз авылыбызда маяк ул», – дип тә җиппәрә.* И.Нәбиуллина. *Ул Мөхәммәт Мәһдиев «бәхилләшкән» таза хәлле, нык әхлаклы, милләтнең умыртка баганасы вазифасын үтәгән авылны юкка чыгарды.* Т.Галиуллин

**УМЫРТКА́ ҖЕЛЕГЕ** *и.* Умырткалыларда үзәк нерв системасының умыртка баганасы эчендә урнашкан өлеше; арка мие. *«Сеңлемнең умыртка җелегеннән пункция алганнарын әни белми дә кала, ул чорда табиблар баланы ничек дәвалаганнарын ата-анага аңлатып та тормаган», – ди Әлфия.* Кызыл таң

**УМЫРТКАЛЫ** *с.* 1) *биол.* Умырткасы булган. *Умырткалы хайваннарның кайбер күзәнәкләре генә фагоцитозга сәләтләрен саклаган.* Биология

2) *күч.* Тотрыклы, нык, какшамас. *Ярый ла мин умырткалы кеше, ә менә беренче тапкыр кызыксынып килеп кергән кеше булса, бик күпләр мәчет картларының дорфа сөйләшүенә аптырап чыгып китә, башка аяк атламый мәчеткә.* Безнең гәҗит

**УМЫРТКАЛЫК** *и. анат.* Кимерчәк ярдәмендә үзара ярымхәрәкәтчел тоташкан сөякләр рәтеннән торган, кеше яки хайван скелетының муеннан билгә кадәр урнашкан нигез өлеше. *Илһамның чәрдәкләнгән умырткалыгындагы җепселләр тәмам өзгәләнгән иде.* Р.Галиуллин

**УМЫРТКАЛЫЛАР** *и. күпл. биол.* Сөяк яки кимерчәк скелеты булган югары төзелешле хайваннарның гомуми исеме. *Күпсанлы буынтыгаяклыларның (бөҗәкләр, кыслалар, үрмәкүчләр) һәм умырткалыларның тиз хәрәкәтләре нәкъ менә шушы мускуллар кыскару белән бәйләнгән.* Биология

**УМЫРТКАСЫЗ** *с.* 1) Умырткасы булмаган, умыртка сөяксез. *Ләкин бу бик үк дөрес түгел: скелет ясалмалары умырткалыларда гына түгел, бәлки башка бик күп умырткасыз хайваннарда да бар.* Биология

2) *күч.* Нигезе, терәге, тотрыгы булмаган; аумакай. *Бикбулат ише умырткасызлары, әнә, дин алыштырды.* М.Әмирханов. *Тик контрольнең чиге булырга тиеш, югыйсә ул кулдан тотып җитәкләп алып баруга әйләнә, күрсәтмә көтеп ятучан, умырткасыз, ихтыярсыз һәм фикерсез кешеләр тәрбияли.* А.Тимергалин

**УМЫРТКАСЫЗЛАР** *и. күпл. биол.* Сөяк яки кимерчәк скелеты булмаган түбән төзелешле хайваннарның гомуми исеме. *Вак сөйрәлүчеләр күбесенчә умырткасызлар белән, башлыча бөҗәкләр белән туклана.* Биология. *Аларның кайберләре, мәсәлән умырткасызлар һәм амфибияләр, корылык вакытында сыенырлык урыннарга яшеренәләр һәм йокыга талалар.* Материклар һәм океаннар географиясе

**УМЫРУ** *ф.* 1) Берәр нәрсәне эләктереп өзү, йолку, каеру, тырнап куптару. *Җиргә тезләнеп, туфракны умыраумыра, илерә-илерә үксегән Дилбәрне этисе Гафур абый сөйрәп дигәндәй торгызды.* А.Әхмәтгалиева. *Кулларын як-ягына җәеп җибәрә дә, катырган бармакларын батырып, туфрагын умырып көрәп ала.* К.Җәмит

2) Ниндидер тоташ әйбернең зур бер өлешен, кисеген куптарып, ертып, аерып төшерү. *Локман, бишмәтенең бер*

*җиңен умырып өзеп алды да, чанада яткан керосин савытын ачып, җиңне керосинга манчыды.* Г.Шәмсетдин. *Җиләкнең нәкъ уртасыннан тишеп чыккан бит [билчән], төбеннән умырып булмый – җиләк тә йолкыныр, тамырына чабып кара – җиләккә дә һәлакәт, яфракларын берәм-берәм умырып ташласаң гына инде.* И.Низамов

3) *күч.* Үзе өчен күп итеп булдыру, ярамаган юллар белән күпләп үзләштерү; үзенеке итеп өлгерү. *Кайберәүләр суганны Беренче май бәйрәменә җитештерәләр, ну, акчаны умыралар инде.* Х.Камалов

4) *күч.* Зур-зур кисәкләр кабып комсызланып ашау. *Гайфулланың авызына аракы керүгә, ач бүре кебек ашый торган гадәте бар иде: табын уртасындагы табакта бөтен килеш пешерелгән тавыкның ботын ботка, канатын канатка ботарлап умырырга тотынды.* Ф.Яруллин. *Шуңа күрә ашауны да умыралар, җиткер генә.* М.Әмирхан

◊ **Умырып алу** 1) Тупас рәвештә нык итеп учлап, тешләп яки башкача эләктерү, тоту. *Әгәр гәҗитегездә өзекләп бастырсаң, кулдан умырып алып укыячаклар.* И.Хәйруллин; 2) Берәр нәрсәне артыгы белән алу, чамадан артык итеп алу. *Егет төскә-биткә начар түгел. Эчми, тартмый. Акчаны умырып ала, сак тота.* А.Гыйләҗев. **Умырып (умыртып) эшләү** Бөтен көчен куеп, яратып эшләү. *Хәер, кая гына куйсаң да умыртып эшләрлек егет ул.* М.Хәсәнов. *Эшен умырып эшләде, акчасын да мул алды.* Г.Әдһәмова

**Умыра башлау** Умырырга тотыну. *Призывниклар, куанычлы кыргый авазлар чыгарып, бер-берсенең киемнәрен умыра башладылар.* З.Мәхмүди

**Умыра бирү** Бернигә карамый умыру, һаман умыру. *[Таминдар:] Чалбар төбен генә умырмаса ярар иде, ләгънәт! [Җәмәй:] Умыра бирсен. Сиңа нәрсә: чалбар төбе булды ни, булмады ни.* И.Юзеев

**Умырып алу** Тиз арада умыру. *Бөркәнгеч эченә бастырык юанлыгы көчле кул керде дә догамны умырып та алды.* М.Әмирханов

**Умырып бетерү** Тәмам умыру, умырылган хәлгә китерү. *Берәүләрнең сөйләве буенча, җирле урман патшалары саналган аюлар, тәрәзәсе ачык калган машиналарга кереп, эчтәге бөтен нәрсәне дөмбәсләп, утыргычларны умырып бетергән очраклар да сирәк күренеш түгел, ди.* Ватаным Татарстан

**Умырып калу** Умырырга өлгерү. *Чыннан да татар берәр түрәлек урынга тиенсә, тизрәк умырып калырга тырыша.* Р.Зәйдулла

**Умырып чыгару** Тулысынча умыру, умырып өзеп, йолкып чыгару. *Тарткалаша торгач, ул, ялгыш эләктереп, матросның күлмәк җиңен төбеннән үк умырып чыгарды.* С.Сабиров

**УМЫРЫК** *и.* Умырып алынган кисәк яки умырылган урын. *Ул карчыкның өстендә пычранып беткән яшел гимнастёрка, култык астында зур гына умырык.* Ф.Сафин. *Көйләр дә нигездә – чеп-чи халтура: аннан-моннан йолкыштырылган умырыкларны корыштырып теркәлгән, япон тактасы банкындагы әзер протез башлам һәм очламнар белән ялганып тәпәләнгән нәмәрсәкәйләр...* Татарстан яшьләре

**УМЫРЫЛУ** *ф. төш. юн. к.* **умыру** (*1, 2 мәгъ.*). *Көрәшә торгач, кайсыбызның җиңе өзелеп чыкты, кайсыбызның чалбар төбе умырылды.* Ф.Яруллин. *Кая карама, әле башланып кына килгән төзелешләрдә очрый торган ташландыклык, актарылган, умырылган җир күзгә ташлана, кай тарафка колак салма, дөпелдәп, ухылдап һәм иңрәп, көчли-көчли, туң җиргә меңләгән, миллионлаган субай каккан бой-бабаларның тетрәткеч тавышлары ишетелә.* А.Хәлим

**Умырыла язу** Чак умырылмый калу

**Умырылып бетү** Тәмам умырылу. *Баскычтан, кабалана-кабалана, өстебашы умырылып беткән Миңлехәбиб менә дә бер ишекнең тоткасын тарта башлый.* Д.Салихов

**Умырылып калу** Умырылырга өлгерү; ниндидер тәэсирдән соң умырылган хәлгә килү. *Гәүдәсен кубарганда, бишмәтенең җиңе умырылып калган, билгеле...* Р.Низамиев

**Умырылып китү** Кинәт умырылу. *Тарта торгач, бер чалбар балагы шытырдап умырылып китте, һәм Костя аягын тәгәрмәч арасыннан йолкып алды.* Х.Камалов

**Умырылып чыгу** Тулысынча умырылу. *Сарайның түбәсендәге калайлар ике урыннан умырылып чыккан.* В.Имамов

**УН** *сан* 1) Тугыздан соң килә торган бөтен сан. *Әле беренче сыйныфта укып азаплана башлаган гына булса да, ул инде хәзер унга кадәр саный да белә.* А.Хәлим. *Марат уннан унны алып ташлаган, ун калган.* Кызыклы арифметика

2) Шул санча микъдар; шул сан микъдары кадәр булган. *Былтыр гына салынган ун катлы матур өй икән, тирә-ягында энә төшәрлек тә урын калмаган.* А.Әхмәтгалиева. *Мин берьюлы ун кешегә каршы уйный алам һәм унысын да отачакмын!* А.Гыймадиев

3) Борынгы дистәле системада административ берәмлек. *Зур авыллар төбәкләргә бүленеп йөртеләләр, кайсы авылларда шул төбәкләрне ун дип йөртәләр.* Г.Лотфи

4) *тар.* Ун кешедән гыйбарәт гаскәри берәмлек

5) Шул хәтле яшь. *Балага ун тулды*

**УНАЛТЫ** *сан* 1) Унбиштән соң килә торган бөтен сан. *Гел бергә артык – унбиш урынына уналтыга чыга икән болар.* Т.Нәҗмиев

2) Шул санча микъдар; шул сан микъдары кадәр булган. *Уналты тиенне учына йомарлап кибеткә барганда, аннан ипи күтәреп кайтканда үзен иң бай кеше итеп хис иткән малай өчен бу – башка сыймаслык зур акча иде.* А.Әхмәтгалиева

3) Шул хәтле яшь. *Акыл да керә башлагандыр инде үзенә, уналтыны тутырып килә бит.* Л.Ихсанова

**УНАР** *сан* 1) Һәркемгә яки һәрнәрсәгә ун, бертигез күләмдә ун булуны белдергән бүлү саны. *Биш министр да, бүленеп, барысы да начар киемнәр киенеп, үзләре белән унар солдат алып таралдылар, ди, илнең төрле ягына.* А.Алиш. *Көннәрдән бер көнне, олырак авыл кызларына ияреп, җәен генә унар яшь тулган ике игезәк кыз Хания белән Хашия дә җиләк җыярга киләләр.* В.Ильясов

2) *к.* **унлап**. *Чабатаның гомеренә килгәндә, кызу эш өстендә авыл кешесенең чабатасы күп дигәндә дүрт көнгә чыдаган, ә кышын унар көнгә җиткән.* А.Тимергалин. *Унар көн авызга кайнар аш кермәгәч, катыкоты ашап тешләре коелып беткән иде.* А.Гыйләҗев

**УНАРЛАГАН** *сан к.* **унлаган**. *Ә менә без моңа кадәр ишетмәгән, белмәгән унарлаган көй чыгаручыларның җырларын иң башта ул башкара.* Р.Миңнуллин

**УНАРЛАП** *рәв.* Унар-унар итеп, дистәләп. *Анда аларны вагоннардан төшереп дүртәрләп тезделәр дә, бер*

*зур елга буена алып килеп, брезент чатырларга унарлап бүлеп тутырдылар.* З.Зәйнуллин. *Унарлап санасаң гына гомерне дөрес исәпләп була.* М.Мәһдиев

**УНАРЛЫ** *с.* Унарлап санауга нигезләнгән. *Акустик бериш конструкциянең тавыш үткәрмәү сәләте аның массасының унарлы логарифмына туры пропорциональ.* Төзү материаллары. *Теләсә нинди реаль санны чиксез унарлы вакланмалар (периодик яки периодик булмаган) рәвешендә күрсәтергә була.* Алгебра

**УНАРЛЫК** *с.* Һәрберсе унлык булган. *Унарлык алтыннар, егерме бишлек кәгазьләр дә, кызыл енот туннар, кыйммәтле ефәк чапаннар да килде.* Г.Ибраһимов. *Миңа бәхетле, озын гомерләр теләп дога кылырсың, энем. Өч унарлык, санап ал, ягъни мәсәлән.* Ш.Камал

**УНА́У** *сан* Нинди дә булса бер төркемдә ун предмет яки зат булуын белдерә торган җыю саны. *Аларның бер генә кеше дә, унау да булулары бар.* Н.Әхмәдиев. *Нәрсә сез бер кешегә унау ябырылдыгыз?* Ф.Яруллин

**УНАУЛАП** *сан* **1.** Чама белән унау, якынча ун кеше яки предмет булуны белдерә торган чама саны. *Кирәк чакта да шулай килмәсләр, әйтерсең лә күпкатлы бина яна: зур гына машинага унаулап төялешкәннәр, бөтенесе дә махсус киемнәрдән, каскалардан, калын шланглар чыгарып, машинага сиптерергә тотындылар ---.* Шәһри Казан

**2.** *рәв. мәгъ.* Ун булып; унысы бергә. *Тау өстендә, чирәмдә Утырабыз җыйнаулап, Бишәү түгел, унаулап.* Ш.Маннур

**УНАУЛАШЫП** *рәв. к.* **унаулап 2.** *Уйнасыннар, әйдә, унаулашып, әмма уйласыннар иң алдан: яхшылыкның апак фәрештәсен бәреп төшертмәбез иңнәрдән!* З.Мансуров

**УНБАШЫ** *и. тар.* Алтын Урда, Казан ханлыклары чорларында ун кешелек гаскәри берәмлек командиры. *Кичкә таба әйтелгән җиргә йөзбашлары, унбашлары, алыплар, сугыш осталары җыелгач, тагын углан аларга үзенең беренче боерыгын җиткерде.* Н.Фәттах. *Унбашы һәм аның яугирләре Галине көтәләр.* И.Хуҗин

**УНБЕР** *сан* 1) Уннан соң килә торган бөтен сан. *Өченче көнне чүәкләрнең санын унбергә җиткерде.* Н.Гыйматдинова

2) Шул санча микъдар; шул сан микъдары кадәр булган. *Унбер егет, бергә җыелып, читтән күзләп төн кичерә.* А.Тимергалин. *Иске йортта унбер ел яшәп, сүзгә дә килмәдек.* А.Хәлим

**УНБИШ** *сан* 1) Ундүрттән соң килә торган бөтен сан. *Ул егермене егерме дип әйтә алмыйча – ике дистә, унбишне дистә ярым дип куя иде.* К.Тинчурин

2) Шул санча микъдар; шул сан микъдары кадәр булган. *Ипи уртача унбиш тиен тора иде, димәк, йөз тәңкәгә уртача алты йөз алтмыш алты «кирпеч» ипи сатып алырга мөмкин иде.* А.Хәмзин. *Дөрес, вәзир, унбиш ел буена син миңа тугрылыклы хезмәт иттең.* А.Гадел

**УНДҮРТ** *сан* 1) Унөчтән соң килә торган бөтен сан. *Бу диванасы ундүртнең кубын юри алдан ук исәпләп куйгандыр әле.* А.Азимов

2) Шул санча микъдар; шул сан микъдары кадәр булган. *Дүрт тарафтан ундүрт эт өрде.* А.Хәлим. *Тын уйсулыкка шәһәрдән дачниклар явы төшкәннең икенче җәендә Әнисә абыстайның уңган казлары ике ояга ундүрт бәпкә чыгардылар.* А.Гыйләҗев

**УНҖИДЕ** *сан* 1) Уналтыдан соң килә торган бөтен сан. *Үземнең беренче мәктәп һәм студент елларын бергә кушканнан соң унҗиде саны килеп чыкты.* Т.Кәримов

2) Шул санча микъдар; шул сан микъдары кадәр булган. *Минеямал апа миңа шул өемнән нәкъ унҗиде данә биш тиенлек санап бирде* А.Хәлим. *Кешене унҗиде тәүлек буена йоклатмасаң, ул акылдан яза.* А.Тимергалин

**УНИВЕРМАГ** *и. рус* Көнкүреш товарларының киң ассортименты сатыла торган зур кибет; универсаль кибет. *Универмаг директоры белән минем исемнән сөйләшегез.* А.Гыйләҗев. *Әле күптән түгел универмагта шул читекләрне бер урыс хатыны караштырып торганын күрдем.* Б.Рәхимова

**УНИВЕРСАЛ** *и. лат.* 1) Бер һөнәрнең төрле тармакларын үзләштергән, яхшы белгән кеше. *[Дәмдинов:] Кыхым! Беләсегез килсә, Дәрья, без бит универсаллар! Без бөтен төр сәнгатьне дә башкарабыз!* Х.Ибраһим. *Заводта андыйларны «универсал» диләр, алар теләсә нинди эшне башкара ала.* К.Латыйпов

2) *астр., геод.* Почмакларны вертикаль һәм горизонталь яссылыкта үлчәү коралы

3) Җиңел автомобильнең арткы утыргычлары артында багаж бүлеге булган ябык кузовлы төре // Шундый автомобиль үзе

**УНИВЕРСАЛЛЫК** *и.* Универсал (*1 мәгъ.*) булу сыйфаты. *Әэшченең универсаллыгы физик эш белән акыл хезмәтенең производствода тигезләнүенә китерә.* К.Латыйпов. *Мырмыр Сәлахиләрнең күп һөнәрле «универсаллыгы»на алмашка техник белем, специальләшү, механизаторларның осталыгы килде, махсус белемле белгечләр хәзер хуҗалыкның һәр тармагында эшне промышленность нигезенә күчерәләр.* М.Рафиков

**УНИВЕРСАЛЬ** *с.* 1) Нәрсәнеңдер һәр ягын яки күпчелек өлешен колачлаган; бертөрле күренешләрнең бөтенесенә дә хас булган. *Бу җәһәттән килешләрнең объект мөнәсәбәтен белдерүен иң универсаль күренеш дип күрсәтергә мөмкин.* Ф.Хисамова. *Дәшмәү – универсаль закончалык.* Безнең гәҗит

2) Төрле максатлар өчен яраклы, төрле функцияләр башкара ала торган. *Кыскасы, Мальта пластинкасы кешелек дөньясының мәдәният тарихында беренче универсаль астрономик корал яки әсбап булганга охшый.* А.Тимергалин

3) Кулыннан күп нәрсә килгән, күп һөнәр белүче; күпкырлы. *Хәмзә – бик универсаль артист, кулыннан килмәгәне юк.* К.Кәримов. *Авыл укытучысы – универсаль белгеч.* Н.Әхмәдиев

**УНИВЕРСАЛЬЛЕК** *и.* Универсаль булу сыйфаты. *Аңа универсальлек хас, ул үзен халыклар культурасының барлык тармакларында күрсәтә.* К.Гыйззәтов. *Каләм куәтен, иҗатчы осталыгын, кешегә соклануны, яшәү – үлемгә мөнәсәбәтне чагылдырган өзекләр дә универсальлеккә ия.* Р.Рахман

**УНИВЕРСАМ** *и. рус* Башлыча азык-төлек сатылган, үз-үзеңә хезмәт күрсәтә торган универсаль кибет. *Әгәр язмыш сине Эстәрлебашка алып барып чыгарса, аның үзәк мәйданындагы универсам янына барып, йөзең белән каршы тауга карап бас әле.* Р.Батулла. *Аңлыйсыңмы: универсамга барсам, анда санитарный көн икән.* Д.Салихов

**УНИВЕРСИА́ДА** *и. лат.* Студентлар арасында төрле спорт төрләре буенча халыкара ярышлар. *Бездә универсиада уздырырга җыеналар.* З.Хәким. *Казанда үткән универсиада программасының унөч төренә тагын берне өстәделәр.* Т.Нәҗмиев

**УНИВЕРСИТЕТ** *и. лат.* 1) Төрле гуманитар һәм төгәл фәннәр буенча

белем бирелә торган югары уку йорты һәм бер үк вакытта фәнни учреждение. *Мин, унынчыны тәмамлагач, Мәскәү университетының журналистика факультетына керергә җыенам.* А.Гыйләҗев. *Шөкер, түзделәр, куып чыгармадылар университеттан.* Г.Гомәр

2) Шул учреждение урнашкан бина. *Җәй җитте, мин зур дәрт белән калага юл алдым, әлеге кызның теге кышкы кичләрдә сөйләгәннәре буенча, аны эзләп, университет аудиторияләрендә, коридорларда йөрдем.* М.Мәһдиев. *Университет алдындагы зур гына мәйданны узып, кибетләр рәтенә җиттеләр.* И.Диндаров

3) *күч.* Белем, тәҗрибә туплау чыганагы. *Түбән Каманың беренче урта мәктәбе безнең өчен тормыш мәктәбе, дөресрәге, тормыш һәм сәнгать университеты булды, дисәм, син килешерсең микән?* Р.Вәлиев

**УНИКАЛЬ** *с. кит.* Сирәк очрый торган, үз ишләре булмаган, бердәнбер. *Бу уникаль тәҗрибә белән уртаклашырга дип, Татарстанга төрле илләрдән белгечләр җыелды.* М.Галиев. *Мондый уникаль ачыш йөз елга бер генә тапкыр ясала.* З.Мәхмүди

**УНИКЕ** *сан* 1) Унбердән соң килә торган бөтен сан. *Әмма дә ләкин каушаганда уникене дүрткә бүлә алмыйм.* З.Мәхмүди

2) Шул санча микъдар; шул сан микъдары кадәр булган. *Сәгать унике тулган, иртәгә эшкә барасы бит, кайтып ятыгыз, егетләр.* А.Алиш. *Икенче елны, яңа кешегә – яңа сыерлар, баштан ук үз көеңне өйрәтерсең, дип, унике башмак тананы, җыеп, Тәнзиләгә тапшырдылар.* А.Гыйләҗев

**УНИКЕ́ИЛЛЕ ЭЧӘК** *и. анат.* Нечкә эчәкнең ашказанынннан башланып киткән өлеше (атамасы бу эчәкнең озынлыгы 12 бармак иңе чамасы булганлыктан ясалган). *Уникеилле эчәк элмәгендә ашказаны асты бизе урнашкан.* Биология. *Уникеилле эчәктә җәрәхәт ачылды, чәчем яртылаш коелды, баш авырта, колак сызлый, хәтер начарайды.* Безнең гәҗит

**У́НИКУМ** *и. лат. кит.* Сирәк очрый торган, ише булмаган, бердәнбер экземпляр (кеше яки предмет). *Хәсән Туфан гына уникум шәхес иде.* Р.Вәлиев. *Чын педагогка фундаменталь белем генә дә җитми хәзер. Моның өчен уникум булырга, тагын тел белән аңлатып булмый торган бик күп башка төрле сыйфатларга ия булырга кирәк...* Мәхм.Хәсәнов

**УНИСЕКС** *и. ингл.* **1.** Кистереп ир-атныкы яки хатын-кызныкы дип билгеләп булмый торган, гомумән ирнекенә, хатын-кызныкына аерылмый торган кием, чәч йөртү стиле һ.б.ш.

**2.** *с. мәгъ.* Һәр ике җенескә дә билгеләнгән, икесе дә куллана алган. *Яшьләрнең гомосексуализмны гадәти күренеш итеп кабул итүенә сәбәпче – унисекс мода.* Безнең гәҗит

**УНИСОН** *и. ит. муз.* 1) Бер үк югарылыктагы берничә авазның яки төрле октавадагы бер үк төрле авазларның берьюлы яңгыравы. *Композитор, сатирик якны күрсәтү өчен, күбрәк унисон ысулын куллана.* Безнең мирас

2) Кәефнең, сүзнең һ.б.ш.ның башка кешенеке белән туры килүе, бердәйлеге

**УНИТАЗ** *и. лат.* Табигый хаҗәт калдыкларын канализациягә агызып җибәрү өчен хезмәт итә торган бәдрәф санитар-техник җайланмасы. *Унитазлар, раковиналар юклыктан икенче ел инде эшсез йөргән ике сантехниктан да берьюлы котылдык.* Н.Әхмәдиев. *Ирекнең теге шешәләрне ташка бәреп ватасы килде, бөкеләрен каерып ачты да аракысын унитазга агызды.* Р.Хәбибуллина

**УНИТАР** *с. фр. махс.* Берләштерелгән, бердәм, бер бөтенне тәшкил иткән. *Русия хөкүмәтенең нияте ачык: бер милләт, бер дин, бер мәдәният, ягъни унитар дәүләт булдыру.* Н.Шәрифуллин. *СССР таркалгач, партиянең унитар системасы җимерелде.* Р.Фәйзуллин

**УНИТАРЛЫК** *и.* Унитар булу сыйфаты. *Дәүләт югарыдан түбәнгә кадәр үзенең унитарлыгы белән аерылып торды.* Мәдәни җомга. *Тарих, спираль кебек, милли республикалардан губернага, яңача әйтсәк, агломерациягә күчә, унитарлык көчәя бара, «русиян» милләте проекты тормышка ашырлык көч куела, ә диннең бер генә булырга тиешлеге, ислам үз чиратында куыла баруына ишарәли.* Безнең гәҗит

**УНИФИКА́ЦИЯ** *и. лат. кит. махс.* Нәрсәләрне дә булса бердәй формага, системага китерү, бертөрле итү эше. *Әлифбада, язуда унификация фәкать шулай гына була ала.* Г.Алпаров. *Андый тигезләүләр, тигезләргә тырышулар, төрле масштабтагы бертөрлелек шаукымнары, унификациягә мәдхия җырлаулар бүгенге чынбарлыкта һәрдаим күренеп кенә торалар.* Н.Шәрифуллин

**УНИФИКА́ЦИЯЛӘНҮ** *ф. төш. юн. к.* **унификацияләү**. *Советлар Союзы унификацияләнгән идеология нигезендә төзелде.* Я.Шәфыйков. *Җыелма тимербетон сәнәгатенең төп юнәлеше – унификацияләнгән конструкцияләр һәм торак төзелеше өчен эшләнмәләр җитештерү.* Төзү материаллары

**УНИФИКА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Унификация ясау. *Һәм киләчәктә шундый аерым чыгарылышларны җыеп, унификацияләп, махсус җыелма тасвирлама итеп чыгарганда тагы да яхшырак булыр иде.* М.Госманов. *Без бу төрлелекне унификацияләр идек.* Р.Әхмәтьянов

**Унификацияләп бетерү** Унификацияләү эшен тәмамлау; булган берсен унификацияләү

**Унификацияли башлау** Унификацияләргә керешү

**У́НИЯ** *и. лат. кит.* 1) Бер хөкемдар идарә иткән дәүләтләр берләшмәсе, союзы. *Моңа көч бирердәй сәбәп чыга: Ломжа аша, Корольләр Юлы дип йөртелгән, соңра Польша – Литва униясе төзелүдә зур әһәмияткә ия булган Варшава – Литва юлы санала.* Д.Гыйсметдин

2) Православие белән католиклык чиркәүләре берләшмәсе. *Ул Папа Иннокентий IV белән чиркәү униясе турында сөйләшүләр алып барган, һәм аны, рус руханиларына ташламалар ясалыр, дип ышандырганнар.* Р.Хәкимов

3) Гомумән нәрсәләрнеңдер берләшүе; бергәлек

**У́НКӨНЛЕК** *и.* 1) Ун көн дәвам итә торган вакыт өлеше; айның өчтән бере; декада. *Июньнең беренче ункөнлеге ахырында бездә беренче тапкыр сезнең районның мәдәният һәм сәнгать көннәре үтте.* Т.Нәҗмиев. *Ләкин бер атна буе зәңгәр күк йөзен томалап, кояшны күрсәтмәгән яңгыр болыты сентябрьнең икенче ункөнлегендә төньяктан исә башлаган салкын җил белән алышынды, куе кара болытлар сыекландылар, уңып-шиңеп калып, кире көньякка агылдылар.* М.Хәбибуллин

2) Берәр нәрсәгә багышланган ун көнлек чара; декада. *Алай гына да түгел, С.Липкин 1957 елда Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате ункөнлегендә Дәрдемәндне аеруча яратып тәрҗемә иткәнен сөйләгән иде.* Н.Хисамов

**УНЛАГАН** *сан* Уннар белән, дистәләр белән исәпләнгән; бик күп.

*Көненә унлаган шундый атаканы кире кайтара идек.* М.Яһудин. *Кич белән исә агаебыз унлаган егет белән салонга килеп керә.* Н.Гыйматдинова

**УНЛАП** *сан* Якынча ун тирәсе, чама белән ун; сигез-ун, ун-унике. *Безнең крейсерда унлап милләт вәкиле хезмәт итә.* А.Хәсәнов. *Станицага унлап большевик үтеп кергән, шуларның берсе синдә.* А.Гыйләҗев

**УНЛАТА** *рәв.* Ун мәртәбә, ун тапкыр артык микъдарда. *Йосыфка хәзер өчләтә генә түгел, унлата авыр иде.* Н.Гыйматдинова. *Хыянәтне күтәрүе авыр, әгәр ул никах түшәгендә кылынса, газабы унлата, йөзләтә көчәя икән.* М.Кәбиров

**УНЛЫ** *с.* **1.** 1) Ун кисәкле, ун данәле, ун компонентлы. *Без монда унлы бүленеш системасына игътибар итмәкче булабыз.* Н.Фәттах

2) Зурлыгы, калынлыгы һ.б. берәр үлчәме унга тигез булган. *Иңсәсенә салган унлы чалгы.* М.Мирза. *Кырыгынчы елларда лампага унлы куык кигезделәр.* Р.Юсупова. *Унлы җептән үреп бәйләнгән кар бизәге генә салкын караватн өстенә өелгән мендәрләрне каплап тора.* К.Кәримов

3) Ун шәм яктылыгы бирә торган (лампа тур.). *Ике җирдә унлы лампалар янгангамы, идарәдә көндезге шыксызлык сизелми, киресенчә, ул бик җанлы, эшлекле кешеләр җыелган урынга охшаган иде.* А.Гыйләҗев. *Шәфәкъ алсу нурга төренгәндә, унлы лампа гөлтгөлт килде дә сүнде.* М.Мәһдиев

**2.** *и. мәгъ.* 1) 10 санының исеме. *Быел фестивальнең төп символы – унлы саны икән.* Безнең гәҗит

2) *к.* **унлык** (*3 мәгъ.*)

3) *сөйл.* «Жигули» автомобиленең унынчы моделе. *Әтием үзенең көмеш төсендәге унлы машинасына кереп утырды.* А.Әхмәтгалиева. *Унлының йөртүчесе әллә ни зыян күрмәгән.* Авыл офыклары

**УНЛЫК** *и.* 1) Ун кешедән яки предметтан гыйбарәт төркем. *Калган өч бәйгедә исә безнекеләр иң яхшы унлыкка керде.* Ватаным Татарстан

2) Кыйммәте ун сум булган акча, ун сумлык. *Пыш-пыш килеп бер санады Басыйр Бариевич, бишлекләрнең почмакларын кайтарды, унлыкларны сөеп тигезләде, иллелекләрне үбәрдәй булып өстә калдырды.* А.Гыйләҗев. *Кабина эчендә, рульдә утырган чибәр генә кызга унлык акча сузды.* З.Зәйнуллин

3) Ун күздән гыйбарәт уен картасы. *Тәре унлыгы белән йөрү*

**УННА́РЧА** *сан. к.* **унлаган**. *Уннарча, йөзләрчә кат кабатланган сүзләр...* Д.Булатова. *Паровозга уннарча платформа һәм шактый санда ябык вагоннар тагылган.* М.Яһудин

**УНӨЧ** *сан* 1) Уникедән соң килә торган бөтен сан. *Ике бишнең ун булуын тиз үк белсә дә, ике унөчнең егерме алты булуы, утыз белән унбишнең кырык биш булуы кебек чобалчыкларны озак исәпләми чыгара алмый иде.* Г.Ибраһимов

2) Шул санча микъдар; шул сан микъдары кадәр булган. *Унөч километрның унберен үттек инде.* В.Нуруллин. *Бер заман шулай, ярминкәләр әле бик шәп чакта, әлмәтле унөч кеше Нөркәйдән кайтып киләләр икән.* А.Гыйләҗев

**УНСИГЕЗ** *сан* 1) Унҗидедән соң килә торган бөтен сан. *Унсигездән бишне алу*

2) Шул санча микъдар; шул сан микъдары кадәр булган. *Актарына торгач, унсигез битле шакмаклы дәфтәр тартып чыгарды.* А.Гыймадиев. *Әйтик, кул белән арыш уруның көнлек нормасы унсигез сутый, әмма уракчылардан берәү дә норма үтәү белән генә калмый, утызар-утыз бишәр сутый уручы хатын-кызлар була иде.* В.Нуруллин

**У́НТЕР** *и. сөйл. к.* **унтер-офицер**. *Малайның бәхете бар икән әле: атасын дус күрү аркасында, Җамали унтер, эшне алдан сизенеп, эшне атасына акрын гына тишкән.* Г.Камал. *Кара шинель кигән Гобәйдулла унтер шунда кылычын бутап, нәрсәдер актарынып йөри, кулларын бутый иде.* С.Җәлал

**У́НТЕРЛЫК** *и. сөйл.* Унтер дәрәҗәсе

**У́НТЕР-ОФИЦЕР** *и. нем. иск. хәрби* 1917 елга кадәрге Россия армиясендә һәм кайбер чит ил армияләрендәге солдатлар арасыннан чыккан кече командир дәрәҗәсе һәм шул дәрәҗәгә ия булган гаскәри. *Тегеннән килүче унтер-офицерга: – Мансуровны алып чыгыгыз! – дип боерык бирде.* Г.Ибраһимов. – *Хатының белән кызың кирәкмәме? – дип, Сергеев әүвәл мыскыллап кына Дөмәйгә сүз катты, ә аннары ат өстендә утырган унтер-офицерга эндәште.* В.Имамов

**УНТУГЫЗ** *сан* 1) Унсигездән соң килә торган бөтен сан. *Бер генә мисал: рус телендә унбердән алып унтугызга кадәр саннар кушылып языла.* Х.Сарьян. *Унбишне унтугызга тапкырласак, дүрт йөз миллиард чамасы багланыш мөмкинлеге килеп чыгар иде.* Х.Госман

2) Шул санча микъдар; шул сан микъдары кадәр булган. *Унтугыз ат алып барган идем.* А.Гыйләҗев. *Тәхет өчен көрәшкән елларда анысы үзенең унтугыз туганын үтертеп бетергән.* В.Имамов

**УНТЫ** *и. эвенк.* Озын кунычлы мех аяк киеме. *Җитмәсә, көннәрнең шактый җылынуына карамастан, ул аякларына унтылар кигән.* А.Хәлим. *Иван Иванович белән Басыйр Бариевич министрга хәстәрләнгән бүләкләрне – тун, бүрек, эт тиресеннән тегелгән унтыларны карадылар һәм, бүреккә чират җиткәч, аптырашта калдылар.* А.Гыйләҗев

**УН-УНБИШ** *сан* Нәрсәнеңдер ун яки унбиш тирәсендә булганын белдергән чама саны. *Ничек кулым барып кисим мин аны: тагы ун-унбиш көннән ямь-яшел яфрак яра, аннары уч-уч чәчәкләре, тәлгәш-тәлгәш миләшләре өй түребезне бизи.* А.Вергазов. *Ел саен диярлек ун-унбиш бәпкә чыгара торган ие.* А.Гыйләҗев

**У́НЪЕЛЛЫК** *и.* **1.** 1) Ун елны эченә алган вакыт арасы. *Узган гасырның 60 нчы елларында иҗатка килгән яшьләр, 30 нчы елларда башланып, сугыштан соңгы унъеллыкта көчәйгән сәяси басым тудырган мәдәни торгынлыктан чыгу юлларын эзлиләр.* Т.Галиуллин. *Шулай да узган унъеллыкта ирешкән уңышларны күрми калу ярамас.* Р.Вәлиев

2) Ун ел элек булып үткән яки башланган берәр вакыйганың еллыгы. *Мин әлеге тапшыруның унъеллыгы уңаеннан уздырылган тантанага барган идем.* Г.Шәйхи. *1999 елның көзендә без шул ук Горький урамындагы бинада «Идел» журналының унъеллыгын бәйрәм иттек.* Р.Юныс

3) *сөйл.* Ун ел гомуми белем бирә торган тулы урта мәктәп. *Әсхия апа да, Зарафәт абый да шул сугыш башланганда унъеллыкны тәмамлаганнар, тик укуларын өзлексез дәвам итә алмаганнар: Зарафәт абый сугышка киткән.* М.Хуҗин. *Малай, унъеллыкны тәмамлап, колхозда эшли башлый.* Р.Батулла

**2.** *с. мәгъ.* Ун ел буена дәвам итә торган, эшләнә торган, ун елга исәпләнгән. *Быел районда унъеллык мәктәпне бетердем.* Т.Гыйззәт. *Инде ике бишьеллык һәм ике унъеллык план үтәлгән.* Татарстан яшьләре

**УНЫНЧЫ** *сан* Рәт, тәртип белән санаганда ун урынында килә торган тәртип саны. *Төрмәгә мин унынчы сәяси булып кердем.* Г.Исхакый. *Фәһимә аның күз каршында: «Син, кызчык-чыпчык, тугызынчы, унынчы сыйныфтагы өрлектәй егетләрне тыңлата алмассың», – дигән фикерне укыды.* Д.Каюмова

**УҢ** *с.* **1.** 1) Гәүдәнең сул ягына, йөрәк ягына каршы булган, шул якка урнашкан. *Менә Галәү уң аягын читкә сузып җибәрде һәм, идәнгә сул аягының үкчәсе белән генә тиеп торган көе, зырылдап әйләнергә тотынды.* Н.Фәттах. --- *аларның каршысына уң колагы ак, сул колагы кара бер көчек килеп чыкты.* Ф.Яруллин

2) Карап торучының шул ягындагы, шул якта урнашкан. *Зәңгәр күккә башлары тигән таулар уң якта, шомлы кара урманнар сул якта --- калдылар.* А.Алиш. *Аның артыннан траншеяның уң флангысына таба сугышчылар ябырылды.* Х.Камалов

3) Сул якка каршы кулныкы яки аякныкы. *Аягына Фәридун абзый иң элек уң ботинкасын киеп йөри башлый.* В.Юныс. – *Минем бияләйнең сулы югалган иде шул, ә бу уң бияләй, – диде очлы күзләрен һаман да Илгизгә текәгән килеш.* Ф.Шәфигуллин

4) Йөз белән агым юнәлешенә, түбәнгә таба карап торганда, сул якка каршы булган (яр тур.). *Гаскәрнең бер өлеше уң ярда кала, бер өлеше аръякка кичә.* М.Хәбибуллин. *Сармат тавының бер калкулыгыннан башланып, яшел үзәнгә агып төшкән елганың уң ярында күчмәләрнең тирмәләре урнашкан.* Р.Сәгъди

5) Тышкы, өске, алгы (кием, материал һ.б.ш.ның ягы тур.). *Койганда эретелгән металл тәңкәнең уң һәм сул ягы көзгедәгечә язылган йомшак таштан эшләнгән калыпка куелган.* А.Мөхәммәдиев. *Ул җөй астар кайма өстеннән генә уза, күлмәкнең уң ягында күренергә тиеш түгел.* Сөембикә. *Ә драпны уң яктан үтүкләргә туры килсә, чүпрәкне нык итеп юешләргә онытмагыз.* Ватаным Татарстан

6) Яхшы, кирәкле, файдалы. *Бергәбергә эшләү дәверендә байтак кына уң эшләр башкарылды, күп кенә язучылар яңа фатирларга күчте.* Л.Хәмидуллин

7) Кулай, уңай, яраклы

8) *сәяси иск.* Партиянең үз эчендә коммунистлар партиясе сәясәтенә каршы булган. *Икенче яклап, Сәгъдиев, коммунистик хәрәкәттә уң оппортунизм чәчәк ата.* С.Хафизов // Партиянең төп массасына яки сәяси, фәлсәфи юнәлеш вәкилләренә караганда реакционрак, консервативрак карашлардагы. *Карл Каутский – Германия социал-демократлар партиясе һәм II Интернационал җитәкчеләреннән берсе, марксизмга хыянәт иткән кеше, уң социалистларның идея остазы һәм аңа юл башлап җибәрүче.* Г.Ибраһимов. *Учредительное собрание Петроградта 1918 елның 5 (18) гыйнварында ачыла, әмма аның составындагы уң эсерлар большевиклар хакимияте тәкъдим иткән карарларны һәм декларацияләрне кабул итү мәсьәләсен тикшерүдән баш тарталар* ---. Г.Исхакый // Яңалыкка, алдынгы карашларга каршы килгән, искелекне яклаган; консерватив, реакцион. --- *азсанлы халыкларның милли йөзләрен югалтуны төп максат иткән большевикларга ахыр чиктә татар зыялыларының уң карашлылары да, сул карашлылары да кирәк түгел иде.* Ф.Галимуллин. *Уң көчләр аны ислам төркемнәрен хуплауда гаепләп чыккач, мин мөселман төркемнәрен хупламыйм, ә аларны яклыйм, дип белдергән ул.* Ватаным Татарстан

**2.** *и. мәгъ.* 1) *кыек кил. форм.* Сулга каршы як, шул тараф, шул юнәлеш. *Хәзер дә ул туры бармый, гел уңга борылырга теләгән сыман атлый, ә үзе шулай да, уңга-сулга борылмыйча, туп-туры бара.* Г.Кутуй. *Текстлар уңнан сулга, өстән аска таба язылган.* М.Зәкиев

2) Парлы әйберләрнең сулга каршы сыңары. *Егетнең аңа этлек эшлисе килеп китте. Бияләйнең уңы һәм сулы булуын бөтенләй исеңнән чыгаргансың бит син!* Ф.Шәфигуллин. *Сул ботинкасына уңы белән басып, зәңгәр бахилны ертып җибәрде.* Д.Булатова

3) **уңнар** *күпл.* Сәясәттә уң **1.** (*8 мәгъ.*) карашлы кешеләр. *Камилнең абыйсы Сөләйман Казан шәһәрендә мәсьүл урында эшли. Ул – уңнар арасында авторитетлы кеше.* Һ.Такташ. *«Унитаризм»ны үткәрү юлында татар уңнарының корган барлык интригалары, провокацияләре юкка чыкты, дип, усал яза Галимҗан Ибраһимов та.* Ә.Еники

◊ **Уң колагың үзеңә** Ишеткән хәбәрне беренче сөйләгән өчен сөенче соралганда әйтәләр. *Рәхмәт яхшы сүзеңә, Уң колагың үзеңә. Хәбәреңә май да бал, Теләгәнең сайлап ал!* Н.Әхмәдиев. *Зөлкәрәм --- «Нефтяник» ресторанны ягына ияк какты. – Сәбәбе дә бар: сөенче! – Әҗереңә уң колагың үзеңә, дияр идем, башта әйт, нинди?* Р.Төхфәтуллин. **Уң канаты** *к.* **уң кулы**. *Ат – ирнең уң канаты инде.* Д.Бүләков. **Уң кулда** Уң якта. *Кадерматкә җитәрәк уң кулда ялгыз трактор туңга сөреп йөри.* Р.Миңнуллин. *Уң кулда кием элгече, аннан ары янына килүгә ыңгыраша башлый торган какшау диван --- тора.* М.Маликова. **Уң кулы** Иң ышанычлы, иң турылыклы, иң якын ярдәмчесе, булышчысы, таянычы. *Бүген ишеттем: секретаребыз Зәки Нури аягын сындырган, ди. Ул минем уң кулым иде. Эшләр читенләшә.* М.Әмир. **Уң күз белән сул күз булу** Икәве бер иштән, бердәм булу. **Уң күзен сул күзеннән кызгана** Үтә саран. **Уңга (да), сулга (да)** Бик күпләп, чамадан арттырып. *Неплюйко шаян сүзләрне уңга да, сулга да сибә.* И.Гази. *Беркөнне мин аның «яратам» сүзен уңга да, сулга да чәчеп йөргәнен, ир-егетләрне перчатка урынына алыштырганын очраклы рәвештә генә белеп алдым.* Сөембикә. **Уңнан да, сулдан да** Һәрьяктан, төрле җирдән. *Бер араны бик югары контральтолы фью да фью ачы итеп сызгырулар уңнан да, сулдан да ишетелеп кенә торды.* А.Хәсәнов. *Ишегалдында уңнан да, сулдан да чебеннәр сыман выжылдап пуләннәр очты.* Н.Гыйматдинова

**УҢАГАЙ** *с.* **1.** Һәрнәрсәне уң кулы белән эшләргә күнеккән яки гомумән уң кулы белән генә эшләгән (кеше тур.); *киресе:* **сулагай**. *Торналыда кем сулагай? Әбүзәр Кызрачев уңагай. Аның уң кулы Флүн дә сулагай түгел.* А.Тимергалин. --- *адәм баласының күбесе уңагай, ул уң кул белән эшләп өйрәнгән.* Н.Әхмәдиев

**2.** *и. мәгъ.* Һәрнәрсәне уң кулы белән эшләргә күнеккән яки гомумән уң кулы белән генә эшләгән кеше. *Сулагай – уң кулы, ә уңагай сул кулы белән беркайчан да эш итми!* Ф.Бәллүр. *Белгечләрнең язуынча, таш гасырда сулагайлар белән уңагайлар тигез булган.* Шәһри Казан

**УҢАЕНА** *бәйл.* 1) Нәрсәнең дә булса юнәлешен күрсәтү өчен кулланыла. *Асты өскә әйләнгән булса да, хәзергә баркас әле йөзмә хәлдә, салмак кына тирбәнә-тирбәнә агым уңаена бара бирә.* С.Сабиров. *Тәрәзәдән завод корпуслары, җил уңаена авышкан сыек*

*төтен тасмалары күренеп тора.* М.Маликова

2) Эш-хәлнең берәр нәрсә җаена туры китереп эшләнүен белдерү өчен кулланыла. *Зәйтүнәсе бәрәңге алынып бетү уңаена кабак бөккәне пешереп, шуның өлгереп җитүен сагалый.* Ә.Гаффар. *Ул аны армиядән кайту уңаена ук үзенә алды, иске «Москвич»ка утыртты, читтән торып укырга кертте.* Т.Галиуллин

3) Эш-хәлнең берәр башка эш-хәрәкәткә, аның тактына туры китереп башкарылуын белдерү өчен кулланыла. *«Баламишкин» --- кебек кыска көйләрне гаҗәп шәп сиптерә парин! Көй уңаена иңбашларын да дәртле генә сикертеп тора, җитмәсә.* Ә.Еники. *Ул, --- колагындагы затлы наушнигыннан агылган дөбер-шатыр музыка уңаена селкенә-селкенә, иртәдән кичкә кадәр шул виртуаль дөнья эчендә кайнаша.* Л.Гыймадиева

**УҢАЙ** *с.* **1.** 1) Файдалану өчен җайлы, ипле, әйбәт. *Күл буеның этюдын ясау өчен моннан да уңай урынны табу мөмкин түгел иде.* Г.Сабитов. *Рәсми кешеләрне борчымыйча, ел саен үзем генә юлга чыгам. Туристларча җиңелчә һәм уңай киемнәрдә.* М.Гәрәев

2) Яшәр, көн күрер өчен җайга салынган, көйләнгән, рәтләнгән, яхшы булган. *Үги аналы гаиләдә --- җылы, уңай тормыш коруы бик кыен.* М.Мәһдиев. *Кайда, нинди алачык бар, кайда уңай шарты булмаган нинди бүлмәләр бар, шунда безне тутырып бетерергә булганнар.* Р.Батулла

3) Берәр нәрсә эшләр өчен җайлы, кулай, туры килгән (вакыт тур.). *Элек тә бу хакта уйланганы бар иде, хәзер исә, уңай форсат чыкты, дип исәпләде. Һәм, озак та үтми, бер очрашуларында ул Рәшидәгә маркизет күлмәклек китерде.* Ә.Еники. *Карт буйдакның уйланып калуын Афзал бик тиз сизеп алды һәм, уңай вакытны кулдан ычкындырасы килмичә, Сәетне көчләп диярлек арбасына утыртты.* Ф.Яруллин

4) Эш итәргә җиңел, әйбәт, кулай, җайлы (кеше, аның сыйфатлары тур.). *--- хуҗа абзыйның иң уңай ягы шул булды: эш сәгате беткәч һәм шулай ук ял көннәрендә дә шофёрына машинадан файдаланырга рөхсәт бирә иде.* Г.Әһдәмова. *Бергә эшләгән иптәшләре – уңай холыклы кешеләр, белемле, тәртипле халык, түзәргә була иде.* К.Кара

5) Ризалык белдергән; тискәре булмаган. *Райкомның ишегеп атлап керү белән, дежурныйдан: – Бүгенге район газетасын китерделәрме? – дип сорады. Уңай җавап алгач, икенче катка кабаланып менеп китте.* Ф.Садриев

6) Хуплау, мактау белдергән; әйбәт, яхшы. *Хәмзиннәрнең чит илләрдә дә уңай бәя алган сүзлеген кулга тотканда, мин Касыйм ага белән кул биреп күрешкәндәй булам.* А.Тимергалин. *Иҗатың турында уңай сүз ишетсәң, син нарасыйларча шатланасың, түбәң күкка тия ---.* Р.Батулла

7) Яхшы сыйфатларга ия, кирәкле үзлекләре булган. *Кытайлар балаларын бары тик уңай үрнәктә генә тәрбиялиләр.* М.Әхмәтҗан. *Әгәр дә язучы уңай типлардан юмористик, йомшак тонда көлсә, Сәлмән карт, староста кебекләрне сатира, үткен ирония белән каезлый.* Ф.Хатипов

8) Куелган таләпләргә җавап бирерлек, туры килә торган; уңышлы, яхшы. *Бу хезмәтнең ике уңай моментына тукталып үтәргә кирәк.* М.Җәлил. *«Яшь йөрәкләр» үзе белән романтизмның күп кенә уңай сыйфатларын алып килде.* М.Хәсәнов

9) *мат.* Нольдән зуррак, плюс тамгасы белән билгеләнгән, плюс билгесе белән йөртелә торган. *Координаталар методын файдалана башлагач кына, тискәре саннар уңай саннар белән тигез хокуклы саннар буларак кабул ителәләр.* Алгебра. *Уңай температура чоры башлану белән, Шишкин һәм Таулы урамындагы йортларның бер өлешен су басуы ихтимал.* Алабуга нуры

10) *физ.* Электрның протон, позитрон һ.б. кисәкчекләре булган төренә караган, шуңа бәйләнешле. *Бер яки берничә электронын югалткан атом уңай корылмага ия була.* Физика. *Җәмгать мунчаларында көн азагына дым арткан саен, гигиена шартлары да начарая: һавада кислород кими, углекислота арта, уңай ионнар күбәя ---.* Сөембикә

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Әйбәт итеп, җиренә җиткереп, тиешле таләпләргә туры китереп. *Альбина уңай итеп эшләнгән иркен ванна бүлмәсенә керде ---.* Ф.Яхин. *Коттеджның арткы ягы ягар, чүп-чар саклар өчен уңай итеп эшләнгән иде.* Р.Мулланурова

2) Җайлы, кулай; отышлы. *Миңа шулай качып баручы дошманның арка ягына кылыч ору бик уңай булды.* Р.Батулла // Ипле. *Юл чемоданы җиңел һәм уңай булып калды.* Ф.Яхин

3) Җиңел генә, җайлы гына, ансат кына, тиз генә. *Трамвай белән Яңа Бистәгә борылып менгән җирдә Казан канализация төзелешенең насослар станциясе кукраеп кала. Ул уңай гына шул хәлгә килмәгән. Аның тарихын һәр эшче белә ---.* А.Алиш. *Баштарак эше уңай гына барса да, миңа инде икенче тапкыр табыш юк, ә чыгымнар зур.* И.Сиражи

4) Яхшы итеп, яхшы яктан гына (эш, хезмәт һ.б.ш.ны бәяләү, фикер әйтү тур.). *А.Әхмәдуллинның гыйльми --- эшчәнлеге җәмәгатьчелек, рәсми оешмалар тарафыннан һәрчак уңай бәяләнеп килде.* Х.Миңнегулов. *Ник дигәндә, Идел-Уралдагы татар язучысына Кырым татарларын уңай итеп күрсәтеп язу инде утызынчы елларда ук тыелган иде.* Ф.Галимуллин

5) Кемнең дә булса файдасына, аның соравын канәгатьләндереп. *Аракы мәсьәләсе илдә уңай хәл ителеп, рестораннар шәхси кулларга күчеп беткәч, безнең яшьлек һөнәребезгә ихтыяҗ бетте.* Т.Галиуллин. *Фәкать 1905 ел башларында җибәрелгән чираттагы үтенеч кәгазенә генә ---, мәсьәлә уңай чишелергә мөмкин, дигән өметләндергеч җавап килә.* Әдипләр

6) Канәгатьләнерлек, яхшы, ярыйсы гына. *Башлык больницага җибәрергә теләсә дә, Фәтхулла агай, --- бәйрәм эчендә үзе илтергә булып, кичектерергә сорады. --- Хәле уңай, имеш, тик эче генә поша, имеш, өйгә кайтса хәзер үк терелер дә иде, имеш ---.* Ш.Камал

7) Әйбәт булып, тәртибе, җае белән. *Бүрәнәләр бер-беренә уңай ятып тора.* Г.Ибраһимов

**3.** *и. мәгъ.* 1) Берәр нәрсәнең юнәлеше, урыны; як, тараф. *Ваһапов җавап бирмәде, әкрен генә торды да: – Мин машиналар янына барам, – дип, шул уңайга атлады.* Х.Камалов. *Нишләп соң алар бу яктан кайталар? Масра бөтенләй икенче уңайда лабаса?* Т.Мөбарәков

2) Берәр нәрсә эшләү өчен туган мөмкинлек, барлыкка килгән форсат, уңышлы очрак. *Эшчеләрне унбишәр көнгә прогулкага чыгардылар. Шул уңайдан файдаланып, әти белән әние, туганнарны күрергә кайттым.* Т.Гыйззәт. *Галимҗан аганың бите алсуланып, рухы күтәрелеп китте. Миңа шул уңайдан файдаланып, аңа элек Кави ага Нәҗминең сәламен, телгән тапшырдым ---.* И.Салахов

◊ **Уңае белән** 1) Берәр нинди очракка бәйле рәвештә. *Ә менә күптән түгел генә телевизордан, Казанда узган Бөтендөнья татарларының III конгрессы уңае белән, Татарстан рәссамнарының зур күргәзмәсен күрсәттеләр.* А.Хәсәнов. *1911 елда Уфада Мөхәммәдьяр Солтановның мөфти булып эшли башлавына 25 ел тулу уңае белән юбилей кичәсе уздырыла.* А.Тимергалин; 2) Сәбәпле, аркасында; нәтиҗәсендә. *Документлар тикшерү мәсьәләсе кузгалу уңае белән, [күпчелек солдатларның] Төхфәт шикелле үк, үз ихтыярлары белән генә фронтны ташлап киткән кешеләр булганлык аңлашылды.* Ш.Камал. *Газеталарда әнә, Куйбышев ГЭСы төзелү уңае белән, Казанны судан саклау буенча инженерлык корылмалары төзелеше баруы турында язалар.* Г.Тавлин. **Уңае (туры) килгәндә** Җае чыкканда, уңай вакыт, форсат, мөмкинлек булганда. *Уңае килгәндә Коцюбинский турында кайбер кыскача гына мәгълүматлар китереп үтү дә артык булмас.* Г.Иделле. **Уңае килгән саен** *к.* **уңае (туры) килгәндә**. *Габдулланың уңае килгән саен оешма правлениесенең эшләрен тәнкыйть итеп чыгышлар ясавы Әхмәдиевнең нервларына тия, канын боза иде.* Ш.Камал. **Уңае килсә (чыкканда, чыккан саен, чыкса)** *к.* **уңае (туры) килгәндә**. *Мәгълүм булганча, «Татар шагыйрьләре» китабына әдәбият сөючеләрнең реакциясе бик кискен була, күпчелек Г.Ибраһимовның халык шагыйре Тукай иҗатына кимсетелүле мөнәсәбәтен кабул итми һәм бу мөнәсәбәтне уңае чыккан саен матбугатта белдереп баралар.* М.Мәһдиев. **Уңаена килү** *к.* **уңаена тору**. *[Маһи:] Аның уңаена килмәсәң, кирәгеңне бирә инде ул.* М.Фәйзи. **Уңаена сыйпау** *к.* **уңаена тору**. *Ахыр чиктә басмачыларның кайнар канлы комагаен сынап, юри уңаена сыйпап карарга да була.* Т.Әйди. **Уңаена сыпыру** *к.* **уңаена тору**. *--- чынбарлыкка тәгаен генә үз карашы булмаганлыктан, ялгышып харап булмыйм дигәндәй, ул күбрәк кеше уңаена сыпырырга ярата.* С.Поварисов. *Аның уңаена сыпырырга вакыты тыгыз Нуриянең, тамакка капкалап алырга да иртәгәге көнне кайгыртырга кирәк.* К.Кара. **Уңаена тору** Кемнең дә булса теләкләренә каршы килмәү, ул дигәнчә генә булу, аныңча эшләү; җаена тору. *--- әтиең сүзенә карамагыз! Ул җаһил дип, сез дә аның уңаена тормагыз!* Р.Камал. *Син, ни, әзрәк уңаена тор тегенең, хуҗалар баш игәнне яраталар бит алар.* К.Кара. **Уңаен карау** Үзеннән алдагы сүз белдергән эш-хәлне үтәргә тырышу, шуны үтәү өчен һәр форсаттан, мөмкинлекләрдән файдалану. *Һич арттыру юк: язын һәркем йорт-җирен чистартып, чүпне читкә чыгару уңаен карый.* Кайбыч таңнары. *Качу уңаен карау. Эшләмәү уңаен гына карау.* **Уңаен табу** Җаен, юлын, мөмкинлеген табу. *– Бер уңаен табып, падишаһ янында бер ялган сүз әйтергә күндер, – диде.* К.Насыйри. *--- җиденче мартда бугай, Габдулла мулла Әмирхани, бер уңаен табып, Фатихның теленнән васыятьләренең кайберләрен әйтдергән ---.* Рухи мирас: әзләнүләр һәм табышлар. **Уңайга китү** Эш яки хәл, сәламәтлек һ.б. уңайлану, җайлану, рәтләнү. *Кулың ничек, азрак уңайга киткән шикелләме?* Г.Бәширов. *Ильич аларга паспортлар да табып биргәч, эшләре уңайга китәр кебек тоелды югыйсә.* Ф.Яхин. *Тормышым җиңеләеп, уңайга китте.* Шәһри Казан

**УҢАЙГА** *бәйл.* 1) Бер эш-хәрәкәтне башкарганда, шуның белән берьюлы икенчесенең дә үтәлүен белдерү өчен кулланыла. *Ул, атының соргылт ялына ябышып килгән уңайга --- җиргә сикереп төште.* А.Вергазов. *Касыйм агай да, гармунын сузган уңайга башын янтайтып, хәрәкәтсез калды.* А.Әхмәтгалиева

2) Нинди дә булса бер эш-хәрәкәт башкарылгач та, шунда ук икенчесе дә үтәлүне белдерү өчен кулланыла. *Илсөяр күзләрен ачып җибәргән уңайга кояшка карады.* Г.Гобәй. *Сугышуның сәбәбен тылмач тәрҗемә иткән уңайга ук, Ляценко бер карарга килгән иде инде ---.* З.Зәйнуллин

3) *к.* **уңаена** (*1 мәгъ.*). *Ак карның саф суы уйнаклап ага, безнең көймә итеп йөртә торган --- тактабыз, бозларга бәрелә-бәрелә, су аккан уңайга бара иде.* Ф.Әмирхан. *Чәчкәйләре сибелеп-сибелеп куя Талгын җилләр искән уңайга.* И.Юзеев

**УҢАЙДА** *бәйл.* 1) Үзеннән алда килгән сүз белән билгеле бер вакыт тирәсен, чамасын белдерү өчен кулланыла. *Мусаның --- аяклары иртәнге уңайда тездән алып, ә кичкә таба бот төпләреннән үк сөм тоймас булып, атлаганда сөйрәлә башлады.* Ш.Маннур. *Әле быел, кар эреп беткәч инде, кичке уңайда очраштылар да Хурияләрнең капка төбендәге эскәмиядә утырып тордылар.* М.Хуҗин

2) *к.* **уңайга** (*1 мәгъ.*). *Беркөнне мәктәптән кайткан уңайда, --- урам очыннан керүгә, ул үз йортлары тарафыннан шакылдаган тавышлар ишетте.* М.Маликова. *– Советлар файдасына эшләүче большевиклар калдырган кеше, дип карадылар. Кыш көне сезнең Әминев белән чигенеп китеп барган уңайда Бирски аркылы узуыгызны һәм бездә туктавыгызны кемдер күрсәткән, – дидем.* З.Кәримова

**УҢАЙЛАНУ** *ф.* 1) Нәрсә дә булса файдалану, куллану өчен уңай хәлгә китерелү, көйләнү, рәтләнү, җайлану. *--- түшәмгә лампа тагар өчен ясалган тимер ыргакка бармак калынлыгы җеп эленгән. Шуның түбән башы, бик иппән, уңайланып, муенчак ясалган.* Г.Ибраһимов

2) Тәртипкә килү, көйләнү, җайга салыну, рәткә керү. *Авыл кырларында нефть табылгач, тормыш уңайланды.* Х.Камалов. *--- уртак тормыш итүчеләрнең иҗтимагый аңы үскән саен, матди ихтыяҗларны канәгатьләндерү мөмкинлекләре, --- яшәү шартлары да уңайлана ---.* Р.Сафин

3) Физик яктан сәламәтләнә бару, савыга, тазара, хәлләнә, рәтләнә, төзәлә башлау. *Хәмит, кулы бераз уңайлану белән больницадан чыгып, авылга килде.* Һ.Такташ. *Галимҗан агай: «Сәламәтлек уңайлангач та, башка әсәрләргә тотыначакмын», – ди.* Г.Кутуй

4) Яхшыру, әйбәтләнү, канәгатьләнерлек хәлгә килү. *Күзе эренләгән иде, дару сөрткәч уңайланды.* Н.Гыйматдинова. *– Һаман авыртамы? – дип сорады Рәшит. – Уколдан соң бераз уңайланды.* Р.Габделхакова. *Тиз арада миңа ярдәм күрсәтте, чәйләр куеп эчереп, хәлем уңайлангач, яктылык иңә башлагач кына кайтып китте.* Безнең Чирмешән

5) Җайга килү, тискәре сыйфатларыннан арыну, яхшы якка үзгәрү, яхшыга әйләнү (кешеләр тур.). *Кире типлар соңгы пәрдәдә уңайланалар да яп-яхшы булып китәләр.* М.Җәлил

**Уңайлана бару** Акрынлап уңайлану. *Тормышыбыз яхшырганнан-яхшыра, уңайланганнан-уңайлана бара ---.* Р.Гарифуллин. *Әмма елдан-ел эш шартлары уңайлана бара.* Әлки хәбәрләре

**Уңайлана башлау** Уңайлану билгеләре күренү. *Доктор авыруы куркынычлы дип тә, куркынычсыз дип тә ачык әйтмәгән. Гангренага сабышмаса,*

*ике-өч көннән уңайлана башлар, дигән.* Ш.Камал. *Көн артыннан көн үтте, --- күзгә таба Абдулланың хәле уңайлана башлады ---.* В.Ильясов

**Уңайлана төшү** Бераз уңайлану. *Михнәтле беренче ел үтеп, икенчесен сүтә башлаганда, тормышлары уңайлана төште.* Р.Хәбибуллина. *Аңа кадәр минем хәл дә уңайлана төшәр, бәлки.* Р.Айзатуллин

**Уңайланып килү** Аз-азлап уңайлану. *Ул, кайбер авырлыклар булса да, сәламәтлеге инде уңайланып килүен әйтте.* Байрак

**Уңайланып китү** Ниндидер этәргечтән, сәбәптән соң уңайлану. *Химия терапияләре алгач, хәле уңайланып китә.* Ватаным Татарстан. *Өйләнешкән яшьләргә йорт төзү өчен тик яткан җирләрне бирсәләр, --- бәлки, хәлләр уңайланып китәр иде дә бит.* Әлмәт таңнары

**УҢАЙЛАП** *рәв.* 1) Ипләп, әдәпле генә, каты бәрелмичә. *Ул-бу булса, Давыд иптәш, Габдәһ абзый аркылы, минем Бакуда калган балаларым белән хатыныма хат җибәртсен, уңайлап аңлатсын!* Г.Ибраһимов

2) Кешенең кәефенә туры китереп, йомшак кына, җайлап, ипләп. *Анасы матур энҗеле калфакларны --- бай бикәләргә илтергә киткән чакта, Һаҗәр ялгызы сүзгә әзерләнә, ничек итеп, ипләп, уңайлап сер ачуның юлларын эзли иде.* Г.Ибраһимов

3) Ипләп, рәтен, тәртибен белеп, тиешенчә, кабаланмыйча. *Атлар да бит илнең бер өлеше – идарә ит җайлап, уңайлап...* Р.Харис

**УҢАЙЛА́У** *ф.* 1) Кулланырга, тотарга, эшләргә җайлы хәлгә китерү, уңайлы итү. *Артында тояк тавышы яңгыравын ишеткәч, --- артык тәшвишләнмәде, пәрәнҗә астында муенына асылган наганын гына капшап, файдаланырга уңайлап куйды.* Т.Әйди. *Уятырга кызганып, шунда гына мендәрләр куеп, урынын уңайладык.* Безнең мирас

2) Нәрсәнедер билгеле бер тәртипкә китерү, тәртипкә кертү, көйләү. *[Бәдри Исмәгыйльгә:] Эшне уңайларга тырыш. Бар, хәзер ул су буенда.* М.Фәйзи. *Сөяксез Гайшә --- намазлыкта аякларын уңайлап утыра да, Алласыннан мәрхәмәт сорый башлый.* З.Зәйнуллин

3) Берәр якка юнәлү, юлга чыгу. *Мин тиз генә кармакларны урадым да балыкны капчыкка салып алдым. Кайтырга уңайладык.* М.Кәрим. *Күз якынлашуга, шулай да борчыла башладылар, киңәш иттеләр: – Махмутка, нишлибез? Монда кыш чыгып булмас, берәр якка уңайлыйк, – диде урыс.* Г.Якупова

**Уңайлап бирү** Кем өчендер уңайланган хәлгә китерү. *«Таттелеком» егетләре матурлап, уңайлап биргән чишмә буен төзек --- итеп саклау вазифасы «көмешле су» чыгаручыларга йөкләнгән.* Шәһри Казан

**Уңайлап кую** Алдан ук уңайлау; уңайланган хәлгә китерү. *Рәшит, әйлешәйле бераз торганнан соң, пенснесын уңайлап куйды да сөйләргә тотынды.* Ф.Әмирхан. *Хатыны, арып китсә, керфек кенә кагып ала – ире, --- тагын уңайлап куя.* А.Әхмәтгалиева

**Уңайлый төшү** Бераз уңайлау; тагы да уңайлау. *Зариф, сыңар кулы белән иңендәге мылтыгын уңайлый төшеп, кызу-кызу атлый башлады.* Ә.Еники

**УҢАЙЛАШУ** *ф. сөйл. к.* **уңайлану**. *1875 елда дамба буенча атлы тимерьюл төзелгәч, шәһәрдән пристаньга кадәрге җиде чакрымлык юл беркадәр уңайлаша.* А.Тимергалин. *Биредә инвалидлар өчен пандуслар эшләнә, кабул итү бүлегендә авыруларның үзләре, аларны китерүчеләр өчен дә шартлар күпкә уңайлашачак.* Ватаным Татарстан

**Уңайлаша бару** Аз-азлап, акрынлап уңайлашу. *--- кыш уздыручыларның тормыш шартлары да чагыштыргысыз уңайлаша бара.* М.Юныс

**Уңайлаша башлау** Уңайлашырга тотыну. *Тормыш уңайлаша башлау*

**Уңайлаша төшү** Беркадәр, бераз уңайлашу; тагын да уңайлашу. *Булачак язучының белем алуы --- өчен монда шартлар тагын да уңайлаша төшә ---.* Әдипләр. *Ягъни мәгълүмат тапшыру ысуллары үзгәрә һәм тизләшә, уңайлаша төшә дигән сүз.* Өмет

**Уңайлашып җитү** Бөтенләй, тулысынча уңайлашкан хәлгә килү. *Яшьләрнең көн итешләре тәмам уңайлашып җитте*

**Уңайлашып китү** Ниндидер сәбәптән, вакыттан соң уңайлашу. *Озак көттергән яңгырлар яугалый башлады, --- кан басымнарыбыз рәтләнде, шешләребез кайтты, уңайлашып киттек.* Ватаным Татарстан

**УҢАЙЛЫ** *с.* **1.** 1) Куллану, файдалану өчен уңай, җайлы, ипле булган. *Тоткынның аякларында --- су үткәрми торган, язгы-көзге пычрак өчен бик уңайлы аяк киеме.* Р.Мостафин. *Коридорда чират көтеп утыручылар өчен уңайлы диваннар куярбыз.* М.Маликова

2) Бар яктан да уңай булган, әйбәт шартлар тудырылган. *Бәхетле, уңайлы, җылы тормыш башланды.* М.Мәһдиев. *Кордашы Нурулла --- кунакка кергән саен, алар менә шушы артык зур --- булмаган уңайлы бүлмәгә үтәләр.* М.Вәлиев

3) Билгеле таләпләргә туры килә торган. *Кулына портфель тоткан --- төрекмән егетеннән, туктатып, кунар өчен уңайлы урын сораштык.* Х.Туфан

4) Вакытлы, иң кулай. *Бу поезд --- кичке якта китә, икенче көнне көндез, уңайлы сәгатьтә Башкортстанга барып керә торган иде.* Ф.Яхин. *Ирмәк иң уңайлы мәл туры килгәнне аңлап: – Гыйзетдин бабай, миңа бәләкәй генә багор саплап бирмәссеңме икән? – диде.* Д.Бүләков

5) Ипле, әйбәт, яхшы, күндәм (холык, табигать, фигыль, характер тур.). *Рифа үзенең бик уңайлы кешеләргә туры килүен аерым бер канәгатьләнү белән сөйләде.* Х.Камалов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Тиешле хәлгә китереп, яраклы итеп, кулай итеп. *[Ж.Фәйзи либреттосы] музыка өчен бик уңайлы һәм ятышлы эшләнгән.* М.Җәлил. *Бүлмәдә җиһаз бик гади, ләкин яшәү өчен һәрнәрсә уңайлы урнаштырылган.* М.Маликова

2) Җиренә җиткереп, яхшы, уңай итеп, тиешле дәрәҗәдә. *Кем терлекчеләр йортын уңайлы, тәртипле итеп җиһазлатты ---, шул Рәфис бит!* А.Вергазов. *Хатын-кыз тракторчыларның тормыш-эш шартларын уңайлы итеп оештыру турындагы мәсьәлә хакында берәү дә баш ватмый.* С.Ибраһимова

**3.** *хәб. функ.* Бик кулай, җайлы, уңай, ипле булу. *Каклаган казны юлда йөртергә уңайлы бит.* М.Юныс. *Болай яшәве җиңелрәк, хуҗага яравы уңайлырак иде.* Г.Мирһади

**УҢАЙЛЫК** *и.* 1) Уңайлы булу, җайлылык. *Һәркем белә: монда милләтләр юк. Тик уңайлык өчен, паспортта булмаса да, тормышта халыкны берничә төркемгә бүлеп йөртәләр ---.* Н.Измайлова

2) Кирәкле, тиешле, уңайлы шартлар, мөмкинлекләр. *Монда даими яшәгән халык --- барлык уңайлыклары булдырылган яңа микрорайоннарга күчерелгән.* Т.Әйди. *Аларны яклаганнар, бу эшкә һәвәсләндергәннәр, яшәешләренә һәм кәсепләренә төрле уңайлыклар тудырганнар.* М.Гайнетдинов

3) Нәрсәнеңдер уңай ягы, файдасы. *Без моңар хәтле семьялар белән монда кучүнең уңайлыгы турында бернича тапкыр сөйләшеп алган идек инде.* Ш.Камал. *Әгәр компания клиентның уңайлыгы турында кайгыртмаса, мондый офиска кешеләр юлны тиз онытачак.* Якты юл

**УҢАЙЛЫЛАНУ** *ф. ялг. к.* **уңайлану** (*1 мәгъ.*). *Елдан-ел шәһәр үсә, матурлана, яшәү өчен уңайлылана.* Яшел Үзән

**Уңайлылана башлау** *к.* **уңайлана башлау**. *Эшләр уңайлылана башлады*

**Уңайлылана бару** *к.* **уңайлана бару**. --- *соңгы елларда район үзәге Җәлил бистәсе дә, авылларыбыз да күзгә күренеп матурлана, төзекләнә, уңайлылана бара.* Сарман

**Уңайлыланып китү** *к.* **уңайланып китү**. *Бүлмәләр, Эмиль Фидаил улы Шәрәфиев килгәч, ничектер яктырып, тагын да уңайлыланып киткән.* Яшел Үзән

**УҢАЙЛЫЛЫК** *и. ялг. к.* **уңайлык**. *Уңайлылык өчен, йөгерешчеләр төркемнәргә бүленде.* Шәһри Казан

**УҢАЙСЫЗ** *с.* **1.** 1) Нәрсә дә булса эшләү, файдалану һ.б.ш. өчен җайсыз, яраклаштырылмаган, җайлаштырылмаган. *Ә дошман безнең гаскәрләрнең кайдан һөҗүм итәчәген алдан белеп, әзерләнеп тора. Әнә шундый ифрат уңайсыз шартларда Волхов һәм Ленинград фронты гаскәрләре дошманга һөҗүм башлыйлар.* Р.Мостафин. *Зират чатында, юлның уңайсыз бер җирендә, шып итеп тормозга басасы урында, бар көчемә газга басканмын.* А.Хәсәнов

2) Уңайлыклары булмаган, комфортсыз. *Уңайсыз бүлмә*

3) Авыр, кыен; күңелсез. *Ул хәзер Хөсәенне уңайсыз бер хәлгә төшерергә тырышуына үзе дә үкенә иде.* А.Расих. *Бүлмәдә әз генә вакытка уңайсыз бер тынлык урнашты.* Н.Фәттах

4) Тиеш булмаган, урынсыз; кирәксез. *Күңел таш түгел бит, уңайсыз бер яктан сүз ачарсың да картның яралы йөрәгенә кагылырсың.* Г.Ибраһимов. *Әгәр дә ки мин, Фирая Әсәтовна, Сезне ялгыш кына уңайсыз сүз әйтеп рәнҗеткәнмен икән, --- мең тапкыр гафу үтенәм.* Т.Миңнуллин

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Җайсыз итеп, ипсез итеп. *Бабай сәламен бирү белән генә туктамады, җиңел кузгалып, миңа уңайсыз рәвештә ике кулын биреп, сүзен тагы өстәде ---.* Г.Ибраһимов. *Хат алганнан соң, Рәмзия Рөстәмовна төне буе керфек какмады, таң атканчы --- тар һәм уңайсыз тоелган караватында боргаланды.* Ф.Галиев

2) Тартынып, уңайсызланып. *Казакилы егет уңайсыз гына елмая да кызара.* Ф.Әмирхан. *[«Бала тапмый торган хатыннар да була бит, ә?» Шул сүздән утырышта бердәнбер хатын-кыз бухгалтер Сәрияга уңайсыз гына күз сирпеп алдылар.* Х.Камалов

3) Күңелсез, ямансу. *Сездән айрылып, туганнар, җәйсыз, уңайсыз тору; Бу тору, әйтергә мөмкиндер, кояш-айсыз тору.* Г.Тукай

**3.** *хәб. функ.* 1) Җайсыз, кыен, читен, уңай түгел. *Иелеп эшләргә уңайсыз*

2) Яхшы түгел, әйбәт түгел; оят. *Әйтергә уңайсыз булса да әйтим: күзләремнән мөлдерәп яшьләр агып китте.* Ш.Камал. --- *чибәр кыз белән бөтен шәһәр күз алдында ул беренче тапкыр кайтып бара... Уңайсыз иде аңа, читен иде. Аяк атлаулары үзгәрде, тыны бүленде, теле тотлыкты, тавышы ямьсезләнде.* А.Гыйләҗев

**УҢАЙСЫЗЛАНУ** I *ф.* 1) Уңайлылыгын югалту, уңайсыз булып китү

2) Уңайсызлык сизү; кыенсыну, оялу, тартыну, читенсенү. *Шунда мин бүгенге көнгә кадәр балачак дустым, сабакташым белән очраша алмавыма --- чын-чыннан оялдым, уңайсызландым.* М.Хәсәнов. *Җәүһәр соравының урынсызрак килеп чыгуыннан уңайсызланды.* Ф.Яруллин

3) Оялудан, тартынудан, кыюсызлыктан нәрсә дә булса эшләргә батырчылык итмәү, йөрәксенмәү. *Иртәгесен Рөстәм бөтенесеннән дә элек уянды. Ләкин ишек ачып чыгып китәргә --- уңайсызланды.* Г.Кутуй. *Егет әллә онытты, әллә салонга узган авыру кеше алдында уңайсызланды – яңадан музыкасын кабызмады.* Р.Гыйззәтуллин

**Уңайсызлана башлау** Уңайсызланырга тотыну. *Табында Атилла юк-юк та абасы Биләүгә күз төшереп алды, абасы исә бу хәлгә уңайсызлана башлады.* М.Хәбибуллин. *Без аны исеме белән атарга уңайсызлана башладык.* Л.-Х.Таналин

**Уңайсызлана бирү** Уңайсызлануын дәвам итү. *Зөлкәрам үзен мактауларыннан уңайсызлана биреп, сүзне икенчегә борып җибәрде.* З.Мурсиев. *Әхмәтҗан, атасы белән бертигез әңгәмә корып утыруыннан уңайсызлана биреп, тамак кырды.* Т.Гарипова

**Уңайсызлана калу** *к.* **уңайсызланып китү**. *Хәзрәтнең зур зәңгәр күзләре бик үткен, алар сине үтәли күрәләр иде шикелле. Анна уңайсызлана калды, --- башын иде.* Г.Бәширов. *Ул инде бу фермага йөзләрчә терлекчеләрнең бик күп колхозлардан, совхозлардан --- тәҗрибә өйрәнергә килүләрен ишеткән иде. Шуңа күрә бераз уңайсызлана калды.* М.Хәсәнов

**Уңайсызлана төшү** Бераз уңайсызлану. – *Рәхим итегез, – диде Гөлшәһидә, бераз уңайсызлана төшеп.* Г.Әпсәләмов. – *Айчибәр, – дидем, бераз уңайсызлана төшеп, – хәзер калып булмый, иң яхшысы, уку елы башланганчы тагын килермен.* Н.Әхмәдиев

**Уңайсызланып бетү** Бик нык уңайсызлану. *Өстәл артына ашарга утыргач, Мортазин алардан уңайсызланып бетте.* В.Имамов. *Тавышлары каты, очып йөриләр, күршеләрдән дә уңайсызланып бетә идем.* Идел таңнары

**Уңайсызланып калу** Көтмәгәндә, кинәт уңайсызлану кичерү. *Мондый алкышлаудан уңайсызланып калган Җәүдәт: – Ышанычыгызны акларга тырышырмын, – диде.* А.Хәлим. – *Харисның синең белән танышасы килә. – Миңниса уңайсызланып калды. Башын аска игән килеш, каш астыннан гына егеткә карады.* А.Фәләх

**Уңайсызланып китү** Нindидер сәбәптән кинәт уңайсызлану. *Аның кечкенә күзләре кешене артык җентекли кебек. Таймас --- уңайсызланып китте.* А.Тимергалин. *Мине күргәч, күрше абый уңайсызланып китте, елмаерга тырышкан кебек булды ---.* Н.Гыйматдинова

**Уңайсызланып кую** Бераз, кыска вакытка уңайсызлану кичерү. *Килененең бу сүзләреннән соң Зөлкамал бераз уңайсызланып куйса да сиздермәскә тырышты.* Г.Галиева. *Таир үзенең сүзләре белән кызны җәфалавына уңайсызланып куйды.* А.Нәҗми

**Уңайсызланып тору** Һәрвакыт, гел уңайсызлану; әле, хәзерге вакытта уңайсызлану. *Аннан ул нигәдер бераз уңайсызланып торды. Әллә ни әйтмәкче иде, тотлыкты.* А.Алиш. *Егетләр уңайсызланып торганда, Җәмилә белән Гөлзифа --- аш бүлмәсенә керәләр.* А.Гадел

**УҢАЙСЫЗЛАНУ** II *и. к.* **уңайсызлык** (*3 мәгъ.*). *Егылган солдат җирдән торып өс-башын каккалады да, уңайсызлануын яшерә алмыйча, старшина-разведчикка карады.* З.Зәйнуллин. *Теге*

*чакта урамда булып узган очрашуны истә тотып булса кирәк, килүче кеше, --- тартына төшеп, уңайсызлану кичереп сөйләшә иде аның белән.* Р.Мөхәммәдиев

**УҢАЙСЫЗЛА́У** *ф.* 1) Комачау итү, уңайсызлык тудыру. *Зәйнулла хаҗиның бу эшеннән соң, Мөхәмммәтханның бугазына бер каты нәрсә утырган шикелле булып, аңар сулыш алырга уңайсызлады.* К.Тинчурин. *Тик совхозның безнең авылдан ерактарак булуы тыгызрак бәгланыш тотарга уңайсызлады.* М.Әмир

2) Борчу, тынычсызлау, мәшәкатьләү. *Сезне уңайсызлыйсым килми*

**Уңайсызлый башлау** Уңайсызларга тотыну. *Безнең кесәләр кузна белән тулдылар. Йөргән чакта --- ботка бәрелеп уңайсызлый башладылар.* Ә.Еники. *Бүлмә эчендә зур ятак белән кәнәфидән башка мебель сыярлык урын юк. Бу хәл мине уңайсызлый башлады.* М.Юныс

**Уңайсызлап тору** Һәрвакыт, гел уңайсызлау; әле, хәзерге вакытта уңайсызлау. *Аңга килгәч тә, сулауны уңайсызлап торган кислород маскасын салып аттым.* Шәһри Казан

**УҢАЙСЫЗЛЫК** *и.* 1) Уңайлыгы булмау, нинди дә булса шартларга яраклаштырылмаганлык, нәрсәгә дә булса җайлаштырылмаган булу; җайсызлык. *Ул үзе, гомер буе күчмә тормыш алып бару аркасында, һәртөрле уңайсызлыкларга күнегеп беткән --- иде шикелле.* А.Тимергалин. *Бу юлның уңайсызлыгыннан, юлсызлыктан машиналылар да, җәяүлеләр дә бик озак вакыт интеккән.* Ватаным Татарстан

2) Авырлык, кыенлык, мәшәкать, азап. *Шәһәрдә мең уңайсызлык, йөз кыенлык сагынып көтеп торган икән Исхакны.* А.Гыйләҗев. *Алсу әтисе белән булган хәлне юл уңайсызлыклары нәтиҗәсе дип фаразлады.* Р.Хәсәнова

3) Уңайсызлану, тартыну, оялу, читенсенү хисе. *Элек мин аңа эчке бер уңайсызлык белән читенсенеп кенә яза идем ---.* А.Гыйләҗев. *Малютин --- Мирсәетне рәнҗетүе өчен уңайсызлык хисе кичереп, өстәлгә китереп сукты.* Р.Мөхәммәдиев

4) Аңлашылмаучылык, кыен хәл. *Әнә шулай, әле чынлап торып яши башлаганчы ук, шундый зур уңайсызлык килеп чыккан иде алар арасында.* В.Нуруллин

**УҢАЛУ** *ф. диал.* Яра бетәшү, төзәлү; сәламәтләнү, савыгу. *Кылыч ярасы уңалыр, тел ярасы уңалмас.* Мәкаль. *Ләкин йөрәктәге утлы йомгакны еллар юшкыны каплап китә алмады, күңел җәрәхәтләре уңалмады, юк...* Д.Булатова

**Уңала башлау** Уңалу билгеләре күренү. *[Галимәнең әнисе] әле аз гына да уңала башламаган йөрәгенә чәнчә --- торган сүзләрне тезү өстенә, үзе үксеп еларга керешә.* М.Гафури

**Уңала төшү** Бераз уңалу, тагын да уңалу. *Акрынлап күңел яралары да уңала төште.* Кызыл таң

**Уңалып бетү** Тәмам уңалу, тулысынча уңалу. *Әле уңалып та бетмәгән яра яңадан сызлый башлады.* Р.Миңнуллин

**У́Ң БУЛУ** *ф.* Уңышлы, нәтиҗәле булу; уңай хәл ителү. *Ах, эшләребез уң була күрсен!* А.Гыйләҗев. *Ярый, кунакларыбыз, хушлашыйк, юлларыгыз уң булсын, исән-сау кайтып җитегез.* Г.Галиева

**УҢГАН** *с.* Эшлекле, эшчән, булдыклы, эш рәтен белә, тормышны яхшы алып бара торган. *Шәрифә әбием бик булган, бик уңган, бик зирәк акыллы карчык иде.* А.Хәсәнов. *Алма, чия --- һәм башка агач һәм куаклар, җиләк, суган, кишер түтәлләре, тәртип белән тезелеп утырган умарталар – искиткеч уңган, булдыклы хуҗалар яшәвенә ишарә.* А.Хәйретдинова

**УҢГАНЛЫК** *и.* Уңган булу, уңган, эшлекле кешегә хас сыйфатлар. *Ул --- хуҗаларының уңганлыкларын, булдыклылыкларын мактады.* А.Алиш. *Чибәрлеге, эшкә уңганлыгы ягыннан да аңа тиңнәр бу тирәдә юктыр, мөгаен.* Г.Галиева

**УҢГА́-СУЛГА** *рәв.* 1) Төрле якка, як-якка. *Теге малай ара-тирә уңга-сулга һәм артына борылып күз төшереп алгалады ---.* Г.Кутуй. *Хәтта океан лайнерларын да уңга-сулга чайкалдырып торган дулкыннар җилсез-яңгырсыз көнне дә басылып тормыйлар.* А.Хәсәнов

2) *куч.* Юкка-барга, кирәкмәгәнгә, мәгънәсезгә. *Кешелекнең җирдәге бөек хыялы коммунизм булгач, әлеге совхоз егетләре дә егәрлекләрен уңга-сулга сарыф итмәскә, ә юлны туп-турыдан коммунизмга тотарга булдылар.* А.Хәсәнов

3) *күч. к.* **уңлы-суллы** (*3 мәгъ.*). *Яшь ханча кәефе өчен һәм хан үзе дәүләт малын уңга-сулга тик тарата.* К.Тинчурин. *Уңга-сулга акча туздырырга өйрәнгән егетләрнең соңгы вакытта хәлләре шәптән түгел иде.* Р.Сәгъди

4) *күч. к.* **уңлы-суллы** (*4 мәгъ.*). *Шәфи Алмас үзе дә баштанаяк мөселманча киенгән – ул төрек подданые ич – «бондый, мыз-мез»ләрне уңгасулга чәчә ---.* Г.Әпсәләмов

◊ **Уңга-сулга карап** Уйлап, чамалап, үлчәп; уяу, сак рәвештә. *Дөрес, каты бәрелмәделәр үзе, әдәп сакладылар. Әмма шулай да, уңга-сулга карап, болай дисәм ничек булыр, алай әйтсәм, үпкәләтмәммме дип, сүзне үлчәп торасы да юк, хатын-кыз хакында турысын әйтергә була иде.* М.Маликова

**УҢДЫРУ** I *ф. йөкл. юн. к.* **уңу** I (*1, 4 мәгъ.*). *Ни тотса да булдыра: Уа, юа – ялт иттерә, Ипи салса – уңдыра.* Ф.Яруллин. *Игенне җир уңдырмады, тир уңдырды лабаса.* Ф.Җамалетдинова

**УҢДЫРУ** II *ф. йөкл. юн. к.* **уңу** II. *--- җәйге эссе кояш аның йөзен кара көрән төскә кертте, пилоткасын, --- гимнастёркасын уңдырды.* Г.Әпсәләмов

**УҢДЫРЫШ** *и.* Туфракның, үсемлекләрне яхшы үстереп, мул уңыш бирә алу сәләте. *Бер басуда күп ел рәттән иген иккәч, туфрак уңдырышы яңадан кайтсын дип, аны ун еллар чамасы ташлауга калдырганнар, эшкәртми токканнар.* Р.Фәхретдинов. *Гомумән, галим-белгечләрнең фикеренчә, Җир шарында туфракның уңдырышы кими бара.* М.Абдуллин

**УҢДЫРЫШЛЫ** *с.* Мул уңыш бирә торган. *Ничәмә-ничә мең гектар уңдырышлы җир сөрелмичә ята, кысыр кала...* А.Тимергалин. *Тирә-якта сузылып киткән киң кырлар уңдырышлы кара туфрактан торалар.* З.Зәйнуллин

**УҢДЫРЫШЛЫЛЫК** *и. к.* **уңдырыш**. *Ашлык чәчә торган җиргә уңдырышлылык куәте бирүче матдәләр – азот, фосфор, калий дигән нәрсәләр.* К.Насыйри. *Н.Г. Садыйков район хуҗалыкларында игенчелек культурасын үстерү, басуларның уңдырышлылыгын күтәрү өчен искиткеч зур хезмәт куйды.* Г.Мөхәмммәтшин

**УҢЛА́П-СУЛЛАП** *рәв.* 1) *к.* **уңлы-суллы** (*1, 3 мәгъ.*). *Әнисә, кинәт очынып, Идмасны уңлап-суллап яңаклый башлады.* Ә.Хәсәнов. *Мине күрүгә, йөгереп килде дә озын кычыткан сабаклары белән шәрә балтырларыма уңлап-суллап бәргәләргә тотынды.* М.Маликова. *Халык акчаларын уңлап-суллап теләсә кемгә таратып яткканнарына йөрәк әрни.* Ватаным Татарстан

2) Төрле яклап, бөтен яктан. *Әләкчеләр, ялагайлар уңлап-суллап Шеф*

*алдында чабышалар, Койрык болгап.* Г.Афзал. *Яный яшен, уңлап-суллап Уткылычын уйната.* Р.Вәлиева

3) Төрле якка, уңга-сулга. *Министерствода эшләгәч тә, мин комедияләрдә сурәтләнә торган эшсез кеше түгел. Уңлап-суллап пичәт кенә сугып утырмыйм.* Т.Миңнуллин. *Сөннәрнең илбашы, эшне тизрәк бетерәм дип, уңлап-суллап кизәнеп һөҗүмгә күчте.* Р.Сәгъди

**УҢЛАШУ** *ф. сәяси* Сәясәттә реакционрак булып китү, уңрак позициягә күчү, уңга (*7 мәгъ.*) әйләнү, уң булып китү. *Ирекле-ирексез бу коммунистлар да уңлашырлар, карашларын үзгәртерләр.* Г.Баруди. *Фракция, бәлки, мөселман фракциясе буларак уңлашмагандыр. Ләкин аерым-аерым депутатлары уңлашканнар.* Г.Исхакый

**Уңлаша башлау** Уңлашуга табан үзгәрү. *Хәзрәт көннән-көн уңлаша башлады.* Һ.Такташ

**Уңлашып бетү** Тәмам уңлашу

**Уңлашып китү** Билгеле моменттан башлап уңлашу

**УҢЛЫК** *и.* Уң (*6 мәгъ.*) карашлар, уңнар позициясе. *Һ.Такташ ниндидер үз йөзе булмаган интернациональ әдәбият булдыру, милли үзенчәлекләргә, әдәбияттагы уңлык (коммунистларча булмаган) күренешләренә каршы көрәш алып баруны төп максат итә.* Татар әдәбияты

**УҢЛЫ́-СУЛЛЫ** *рәв.* 1) Әле уң якка, әле сул якка. *Аның шушы шәп егетнең яңагына уңлы-суллы чабып җибәрәсе килде.* Н.Фәттах. *Җил, ялкын телләрен уңлы-суллы бутады да, кинәт кенә көнчыгышка таба авышты.* Н.Гыйматдинова. *Сабирның уңлы-суллы йөрүләренә гаҗәпләнгән Арча хатыннары: – Каймактан авыз итегез! – Сөтемне кабып карагыз! – диде.* Ф.Яхин

2) Уңны сулга, сулны уңга, киресенчә (парлы киемнәр тур.). *Киенә башлагач, плащының җиңен таба алмый интекте, соңыннан, анысының очына-кырыена чыккач, аяк киемнәрен уңлы-суллы киеп куйды.* Н.Әхмәдиев

3) *күч.* Теләсә ничек, күпләп, төрле җиргә (акча, мал һ.б.ш.ны теләсә кемгә бирү, тарату тур.). *Бу әйберләрнең нәрсәгә сатып алынуын һәм төялүен дә, Роллингның миллионнарын нигә шулай башсызланып уңлы-суллы туздыруын да һич аңлый алмады.* А.Толстой. *Малын уңлы-суллы өләшкән ыштансызлар өчен сөенергә минем башыма тай типмәгән лә!* Н.Гыйматдинова

4) *күч.* Күпләп, мул итеп, кызганмыйча (сүз, гайбәт, вәгъдә һ.б.ш.ны тарату, күпләргә җиткерү, ирештерү). *«Яратам» дигән сүзне уңлы-суллы чәчеп йөрү җиңел.* А.Гыйләҗев. *Бу көннән соң Сәримә Гөлчирә турында авылда уңлы-суллы гайбәт чәчте.* Д.Каюмова

5) *күч.* Төрле яклап (тәнкыйть яуды-ру, үгет-нәсыйхәт, акыл бирү һ.б.ш.). *Миңа гына дигән бәхет Мине читләп үткәндә дә, Наширләрем уңлы-суллы Китабымны тузгытканда --- да, Син йөзеңне чөермисең.* Н.Әхмәдиев. *Уңлы-суллы тәнкыйтьләр ява башлау*

6) *күч.* Төрле җирдә, тегендә-монда. *Язмыш мине егерме ел буе уңлы-суллы йөртте.* Ф.Гыйматдинов

**У́ҢМАГАН** *с.* Эшлексез, булдыксыз, юньсез, эш рәтен белми торган. *Кояш баеганда көтүеңне алып кайтасың; аннан соң ашарга, эчәргә кирәк; җитмәсә тагын, кайбер уңмаган киленнәр шул арыш чумарын да син кайтканчы өлгертә алмаган була.* Г.Ибраһимов. *Аннары --- шәхси тормышында, өй эчендә рәхәт күрәсе килгәнен, ләкин бу рәхәтнең, уңмаган хатыны аркасында, юклыгын аңлатты.* Г.Кутуй

**У́Ң-СУЛ** *и.* 1) Нәрсәнең дә булса уң һәм сул ягы. *Бу дөньяның иге-чиге дә, күкнең очы-кырые да, уңы-сулы, алды-арты да юк икән.* Ф.Садриев. *Биясенең уңы-сулында марилар һаман бәхәс кылып басып тора ---.* Ф.Яхин

2) Парлы киемнәрнең уң аяк (кул) белән сул аяк (кул) сыңарындагы аерма. *Галошның уңын-сулын белмәү*

3) Тирә-як, әйләнә-тирә. *Кеше бил бәйләсә бу гыйшык юлында, Шөбһәсен калдырмас уңы-сулында.* Дастан. *Сабакка калмаса соңга, борылмый барса уң-сулга, Уенга салмаса ихлас – менә бәхете аның шунда.* Г.Тукай. *Нәфисә әби авызын сөякле учы белән тоткан килеш кенә уңы-сулына карап алды.* Сөембикә

◊ **Уңны-сулны абайламау** *к.* **уңны-сулны аермау**. *Анда исә өстәлләр буш диярлек, тамашачы берән-сәрән генә. Безнекеләр баштарак, уңны-сулны абайламыйчарак дигәндәй, миңгерәп утырдылар.* М.Маликова. **Уңны-сулны аермау** Эш-хәлләрне, тормышны, кешеләрне аңлап бетермәү; тәҗрибә булмау. *Күрәм: яшь чагында сез сәнгать тирәсендә чыннан да шактый чуалгансыз, ләкин Селифан кебек уңны-сулны аермагансыз. Хәзер дә аермыйсыз.* Г.Әпсәләмов. *Югыйсә Фәргать уңны-сулны аермый торган, берни аңламас кеше дә түгел.* Н.Хәсәнов. **Уңны-сулны белмәү** *к.* **уңны-сулны аермау**. *Хәзер гади игенче булса да, китап-газета күрмәгән, уңны-сулны белмәгән мужик түгел.* М.Әмир. *Шул башбирмәс еллар – кайнар яшьлек – Уңны-сулны белмәс булганга Кагылганмын былбыл оясына Һәм басканмын кара еланга.* Р.Батулла. **Уңны-сулны карамый(ча), белми(чә), күрми(чә)** 1) Як-якка, тирә-юньгә бөтенләй игътибар итмичә. *«Газиз катыны» танк булып безнең өскә килә башлады, безнең чыдамлык җитмәде, --- уңны-сулны белмичә, төрле якка торып йөгердек.* М.Мәһдиев. *Микәй, алны-артны, уңны-сулны белми, аяклары кая илтсә, шунда томырылды.* Р.Мөхәммәдиев; 2) Бернәрсә белән дә исәпләшмичә, бик нык мавыгып. *Алны-артны, уңны-сулны белмичә утын да кистеңме әллә, шаян малай?* И.Юзеев. *Тагын беравыктан уңны-сулны белмичә ярсып эшләгән Искәндәр Фидаяров, үткен чалгы кисеп ташлаган үлән сабагыдай, соргылт ком өстенә авып төште...* Г.Үзиле; 3) Әүвәлен-ахырын уйламыйча, сукырларча. *Шулай да мөфти Илдус Фәиз татар имамнары җыенында, китапларны уңны-сулны карамыйча тыю киеренкелек китереп чыгарырга мөмкин, Алла сакласын, дип куйды.* Татар заманы

**УҢУ** I *ф.* 1) Мул уңыш бирү; бик яхшы үсү. *Быел кишер, чөгендер нык уңды.* Н.Нәҗми. *Бәхеткә каршы, ул көздә иген каерылып уңды.* Г.Сабитов. *Ул елны үтереп алма уңды.* Ә.Галиева

2) Яхшы, нәтиҗәле булу, яхшы нәтиҗә бирү, уңышлы чыгу. *Авылда --- әнисе озатып калгангамы, Мансурның юлы уңды: ике көннән төзү материаллары заводына шофёр булып урнашып --- кайтып керде.* Г.Галиев. *Болай эшләре уңды: ике көн вакытны исраф итү бәрабәренә дигәндәй, иң кирәкле запчастьләр эшләтеп алдылар.* Ф.Садриев

3) Әйбәт кеше туры килү; берәр нәрсә яхшы булып чыгу, берәр нәрсәдән бәхет булу, игелек күрү. *Тарантасын ясап та өлгерми Сәләхетдин, айгырдан уңмавына төшенә.* К.Миңлебаев. *Ир кеше бәхетле булсын өчен өч шарт кирәк: хатыннан уңу, сыердан уңу һәм яңа йортка чыгарган мичтән уңу.* М.Мәһдиев. *Яңа фатирга күчкәч, күршеләреннән бик уңды Сәләх.* Ф.Яруллин

4) Әйбәт булып кабарып пешү, тиешле нәрсәләре җитәрлек салынып

әзерләнгән булу. *Коймагына күз салса, сөбханалла, кабарып менгән, пешерә башламасаң, таша бит бу хәзер. Гөжелдәтеп кенә пешереп тә куйды. Һай, камырының уңганлыгы, коймагының тәмлелеге...* Г.Галиева. *Бүген аның ипие уңган, бүген ул – шушы урамда королева, патша хатыны, ханша, тагын әллә кем.* М.Мәһдиев

**УҢУ** II *ф.* 1) Берәр сәбәптән әйбернең төсе сулу, буявы, төсе югалу, төссезләнү. *Аның өстендә кыска җиңле, төсе уңган алсу ситсы күлмәктән башка берни юк иде.* Н.Фәттах. *Зәңгәр тышлы катыргы төрле кулларда йөреп уңды.* Х.Ибраһим

2) *куч.* Җанлылыгы, җетелеге китү, үткенлеге кимү, тоныклану. *Фаягөл карчыкның --- кайчандыр җете зәңгәр булып, инде төсе уңган күзләрендә арыганлык, чарасызлык билгеләре чагылды.* А.Әхмәтгалиева

**Уңа бару** Торган саен ныграк уңу. *Табигатьнең яшел бизәге хәзер күзгә күренеп уңа бара ---.* Н.Фәттах. *«Хәбәрсез югалган» дигән сары кәгазьнең еллар үткәч төсе уңа барса да, без аны әтинең соңгы истәлеге итеп күз карасыдай сакладык.* Безнең гәҗит

**Уңа башлау** Уңырга тотыну. *Табындагыларның, бер-берсеннән туеп, күз карашлары уңа башлаган чагы...* М.Галиев. *Әбекәй төсе уңа башлаган озын чуар күлмәк кигән ---.* А.Мансуров

**Уңа төшү** Бераз уңу; тагын да ныграк уңу. *Кайчандыр чем кара булган кашлары да әз генә уңа төшкән.* Г.Әпсәләмов. *Аның өстендә ямаулы иске шинель, башында төсе уңа төшкән --- пилотка --- була.* Р.Мостафин

**Уңып бетү** Тәмам уңу. *Әхмәтнең өстендә әллә кайчан уңып беткән иске киндер күлмәк, ыштан ертыгыннан тез башы күренеп тора.* Г.Бәширов. *Клуб һәм мәктәп тирәләрендәге --- язулары уңып беткән лозунгларны тиз генә яңартып куйдылар.* В.Нуруллин

**Уңып китү** Бераз, җиңелчә генә уңу. *Ул кайчандыр Кара диңгез суларында юылып, яшел төсе уңып киткән --- арзанлы пластик йөзгечләрен үзе белән алып килгән иде.* М.Маликова. *Элек зәп-зәңгәр булып янып торган күзләре уңып киткән, тоныкланып калган.* А.Әхмәтгалиева

**УҢЫШ** *и.* 1) Иген, җиләк-җимеш, яшелчә һ.б.ның җыелган күләме, чыгышы. *Ул елларда --- борчак, солы, ясмыкише нәрсәләрнең мул уңышы турында әйткән дә юк.* М.Хәсәнов. *Без шикәр чөгендереннән 200 әр центнер уңыш алу өчен көрәшәбез.* Т.Нәҗмиев

2) Өлгергән, үсеп җиткән иген, яшелчә, җиләк-җимеш һ.б.ш.ның бик зур күләме, мул җыемы. *Фәйрүзәнең басуыннан Шундый уңыш алынган: Андый уңыш һичбер вакыт Булмаган бу районда.* М.Җәлил

3) Эш-хәрәкәтнең хезмәт, тырышлык, акыл, сәләт белән зур көч куеп яулап алынган уңай нәтиҗәсе; казаныш. *Шамил Шәрифуллин иҗаты турында сүз алып барганда, аның җыр өлкәсендәге уңышларына күз йомып үтсәк, бу гөнаһ булыр иде.* Б.Рәхимова. *Данлы җиңүләрне, сугыштагы уңышларны хәбәр итеп, озак көтелгән яз җитте.* Р.Кәримова

◊ **Уңыш бәйрәме** Көзен кыр эшләре төгәлләнгәч үткәрелә торган бәйрәм. *Урып җыю эшләре тәмамлангач, әле яңа өлгергән культура сараенда уңыш бәйрәме булды.* А.Хәсәнов. **Уңыштан баш әйләнү** Ирешелгәннәр белән артык мавыгып, мактанып, канәгатьләнеп, алга табан тырышмау. *Уңыштан башы әйләнә, күңел бушлыгын әлеге дә баягы зарарлы гадәтләр белән тутырырга тотына.* Сөембикә

**УҢЫШЛЫ** *с.* **1.** 1) Югары уңыш алынган. *Биктимер чыгып киткәндә, сугыш алдындагы уңышлы елларда, трудка алынган икмәк ел буена җитәрлек иде әле.* З.Зәйнуллин

2) Уңышка ирешкән, уңай нәтиҗәләр биргән, нәтиҗәле. *Язучылар делегациясе, башка уңышлы эшләр белән беррәттән, менә бу мәйданда да тарихка кирәклек эшләр эшләде.* Г.Кутуй. *Табиблар, чыннан да, кызның күзенә уңышлы операция ясыйлар.* Ф.Хатипов

3) Уңыш белән тәмамланган, җиңүле. *Информбюро көн саен диярлек безнең гаскәрләрнең уңышлы һөҗүме турында хәбәр итә.* Г.Әпсәләмов. *Сталин куйган гомуми бурыч искиткеч мөһим. Ул бурыч Мәскәү янындагы уңышлы операцияне дәвам итеп, 1942 елда илебезне фашистлардан тулысынча чистартудан гыйбарәт.* М.Әмирханов

4) Әйбәт, хуплауга лаеклы, яхшы. *«Абай» операсы – казакъ опера сәхнәсенең иң уңышлы әсәре.* Л.Хәмидуллин. *М.Мәһдиев үзенең мәкаләсендә, Ф.Энгельсның реализм турындагы фикерләрен XX йөз башы татар әдәбияты мисалында тикшерү – бу хезмәттә уңышлы урыннарның берсе, дип саный.* И.Нуруллин

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Уңыш белән, нәтиҗәле итеп; яхшы. *Аның әле бер дә таңга таба болай әсәрләнеп, дәртләнеп атлаганы юк иде. Әллә шул уңышлы тапшырылган имтиханнар куанычы, дүртле-бишле билгеләре җанга рәхәт, тәнгә куәт бирде.* Д.Каюмова. *Уңышлы уздырылган һөҗүм операциясе өчен, Семён Будённый һәм Алексей Антонов Хәрби Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнәләр.* З.Зәйнуллин

2) Урынлы итеп; бик яхшы. *Әнә шуңа күрә повестьның исеме – «Тормыш баскычлары» – бик төгәл һәм уңышлы сайланган дип әйтә алабыз.* М.Мәһдиев

3) Тиешенчә, кирәгенчә, таләп ителгәнчә. *Урманыгызга бара торган юл уңаендагы чишмә буен һәм андагы таллыкны ясыйсы бар. Фотога төшереп кайткан идем, фоторәсем бигүк уңышлы чыкмаган.* З.Хәким

**УҢЫШЛЫК** *и. ялг. к.* **уңыш** (*3 мәгъ.*). *Полкның соңгы елны сугыш кырларында күрсәткән уңышлыклары – майор Арслан Исхаковның да уңышлыклары ул.* Г.Кутуй. *Сезгә --- кайнар сәламнәремне җибәреп, исәнлекләр, көндәлек эшегездә зур уңышлыкларга ирешүегезне теләп калам!* Р.Мөхәммәдиев

**УҢЫШСЫЗ** *с.* **1.** 1) Уңыш (*1 мәгъ.*) аз булган яки бөтенләй булмаган, ач. *Уңышсыз ел*

2) Көткән нәтиҗә бирмәгән, уңыш белән тәмамланмаган. *Теге уңышсыз һөҗүмнән соң, хәлне коткарып калуын искә алып, ул Идрисовны комбат итеп билгеләгән иде.* Х.Камалов. *Санкцияләр сугышында азык-төлекне төп корал итеп куллану уңышсыз гамәл икәнлеген күрсәткән – читтән ризык кертүне тыю көтелгән нәтиҗәне бирмәгән.* Татарстан яшьләре

3) Дөрес булмаган; урынсыз, кирәкмәгән, тиешсез. *Берәр уңышсыз сүз ычкындырырмын, дип курка идем мин.* М.Әмир. *Биредә сүз аерым уңышсыз җөмләләр турында гына бармый, сүз принцип турында бара.* Р.Мостафин

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Уңыш (*1 мәгъ.*) алмыйча, уңыш булмый торып

2) Нәтиҗәсез. *Кичәге эзләнүләр бер төрле дә нәтиҗә бирмәде, --- җинаятьчеләр көймәгә утырып киткәннәр, ахрысы. Вокзаллардан эзләү дә уңышсыз бетте ---.* А.Толстой. *Альбертның атасы хәрби бүлек җитәкчелеге белән беренче ике көндә телефон аша сөйләшә алса да, соңрак алар белән*

*элемтәгә керү тырышлыгы уңышсыз булган.* Н.Акмал

3) Тиешенчә, кирәгенчә, таләп ителгәнчә түгел. *Фәләнгә операция ясаганнар, уңышсыз чыккан, өмет юк, дигәннәр.* А.Тимергалин. *Морат көрәшер! Урынында нык утыра. Бер проект уңышсыз чыккан өчен генә аның даны кимемәс.* М.Маликова. *Роль уңышсыз чыга.* Р.Батулла

**УҢЫШСЫЗЛЫК** *и.* Уңышсыз булу, көтелгәнгә, омтылганга ирешә алмау, тискәре нәтиҗә. *Соңгы имтиханда уңышсызлыкка очрау – гомер буена кала торган үкенеч бит.* Г.Әпсәләмов

**УП** I *и. иск.* Ындыр табагы, ашлыкны сугу, бастыру урыны

◊ **Уп үгезе** Төп эшне башкаручы

**УП** II *иярт.* Зур күләмле нәрсәдер кинәт килеп төшү, аву рәвешен белдерә

**У́П ИТҮ** *ф.* 1) Кисәк авып китү, килеп төшү. *Мена ул күкрәк тутырып башлап җибәрә, минсиңайтим, колач җитмәслек Кайбыч имәннәренең данын үзегез беләсез инде: әсәрләнүдән нишләргә белмичә, тамырларыннан кубарылып, бермәл һавада асылынып торалар да, җыр туктагач, уп итеп кабат урыннарына төшеп утыралар.* Н.Гамбәр

2) Балалар телендә: егылу

**УПКЫН** *и.* 1) Текә һәм тирән яр; җир өстендә бик тирән булып убылып төшкән, төпсез булып күренгән батынкылык. *Ул коточкыч зур һәм төпсез упкын читенә килеп баскан һәм түбәнгә мәтәлүдән котылу өчен берниндиԥ чара күрү дә мөмкин булмаган кеше шикелле хис итә иде үзен.* В.Нуруллин. *Упкынга карарга ярамый, карасаң – беттең: башың әйләнеп, төпсез упкынга очасың.* А.Вергазов

2) Елга, күл яки диңгез төбендәге тирән чокыр; чоңгыл. *Нәкъ елга уртасында бер упкын бар, шунда җиткәч, чыннан да суга ташламакчы идем үзеңне.* Г.Әпсәләмов. *Йөгерер дә алар сикererләр, Диңгез диеп, чиксез упкынга.* Б.Ибраһим

3) *күч.* Кемнәр яки нәрсәләрдер арасындагы чиксез зур аерма, каршылык. *Илаһыбыз безгә яратылыш процессын җанлы мисалларда махсус кат-кат кабатлап күрсәтә дип аңласак, фән белән дин арасындагы капма-каршылыкның, упкынның эзе дә калмый!* А.Тимергалин. *Ирнең дә, хатынның да чигенергә исәбе күренмәде, ике арадагы упкын киңәя генә барды.* В.Имамов

4) *күч.* Тирәнлек. *Уйлар упкынына батып шушы кадәр җир килгән Нәҗип, уянып, Фәридун Фазлыев яшәгән йортны күзәтте.* А.Гыйләҗев.

5) *күч.* Үзенә тартып һәлак итә, начар хәлгә төшерә торган нәрсә. *Юк, ул бернәрсә дә хәтерләми. Башкасын хәтерләми. Хәтерсезлек упкынына очканын гына хәтерли...* А.Хәлим

**УПОЛНОМО́ЧЕННЫЙ** *и. рус иск.* Нинди дә булса вәкаләтләр нигезендә эш итүче рәсми зат; вәкаләтле вәкил, вәкил. *Аларның сөйләүләренә караганда, мине волостной сходта уполномоченный итеп сайларга хәзерләнәләр иде.* Г.Исхакый. *Акылга җиңелсу булса да, чибәрлеге белән уполномоченныйны кызыктырган, күрәсең.* Н.Көбәш

**УПРА́ВА** *и. рус* 1) *тар.* 1917 елгы революциягә кадәр Россиядә административ һәм хуҗалык эшләре белән җитәкчелек итә торган учреждение; идарә. *Бервакытны бер гласный шулай һәр көн өеннән: «Мин управага менәм», – дип чыгып китә икән.* Г.Камал. *Калада мондый хәл ишетелсә, ул шәкертләрне управага чакыртып, зиндан чокырының тирәнлеген үлчәтерләр иде дә бит, болар алай түгел, булганны да күрмәмешкә салынып, юкны бар кебек сөйләргә генә осталар.* Ф.Яхин

2) *сөйл.* Башбаштаклыкка, тәртипсезлеккә юл куймас өчен, кулда тоту чарасы, йөгәнләү, буйсындыру әмәле. *Әхмәдиевнең мактауларыннан башың әйләнде, ахры, үзеңә управа юк, дип уйлый башладың, болар гына җитмәгән, хатыныңны психбольницага илтеп тыктың.* Г.Галиева. *Син нәрсә, малай актыгы! Управа табылмас, дип уйлыйсыңмы әллә?* Г.Гыйльманов. *Әгәр колхоз малын суеп транжиравайт итүегезне туктатмасагыз, без сезгә ынкывыды аркылы управаны тиз табарбыз.* З.Зәйнуллин

**УПРАВДОМ** *и. рус сөйл.* Торак йортлардан файдалануны тәэмин итеп торган учреждение мөдире. *Мин Норильскида управдом булып эшли идем.* Р.Мостафин. *Алар инде череп баеп беткәннәр, дип сөйлиләр, ә бер энеләре, бездә управдом булып эшләүче Каюм Салахович, имеш, сандык-сандык малын каядыр җиргә күмеп куйган, дип тә сөйлиләр иде.* Т.Нурмөхәммәтов

**УПРАВЛЕ́НИЕ** *и. рус* Нинди дә булса учреждение, оешма һ.б.ш.ларны берләштергән административ орган; идарә. *Язылган икенче адрес белән барасың. Ул – НКВД управлениесе.* З.Зәйнуллин. *Аны Кукмарадан управление начальнигы Мәүлин чакырып китерген.* Т.Нәҗмиев

**УПРАВЛЯ́ЮЩИЙ** *и. рус* Нинди дә булса учреждение, оешма, бүлек һ.б.ш. белән җитәкчелек итүче; мөдир. *«Ник барасың?» – дигән сөалемә кыз: «Ирем янына барам, ул анда управляющий булып тора», – дип җавап бирде.* Г.Исхакый. *Ниһаять, һәр көтү үз юлы белән китте дигәндә генә, йокы бүлмәсе хәтле тарантаска берүзе җәелеп, совхоз управляющие килеп җитте.* К.Кәримов

**У́ПТЫМ** *рәв. рус сөйл.* 1) Күпләп, күмәртәләп. *Язмыш аны ваклап сатты... Ә заманы Уптым сата талчукта.* Л.Зөлкарнәй. *Мөмкин – уптым, мөмкин ваклап сатарга. Әҗәткә дә биреп була.* М.Мирза

2) Барысын бергә, берьюлы; берсен дә калдырмыйча. *Кальга сакчылары барысын да озын-озын баскычлары белән бергә уптым чокырга гына аударып торалар.* З.Мәхмүди. *Мужет, сезнең өчегезне берочтан Себер сөрү яхшырактыр. Сезнең атагыз мине сөргән төсле. Җәлләмичә-нитмичә. Тулаем, уптым. Я, ник дәшмисез?* В.Имамов

◊ **Уптым илаһи** *сөйл.* 1) *к.* **уптым** (*2 мәгъ.*). *Шунда барыбыз бергә перронга чыгарбыз да бөтен кирәк-яракны уптым илаһи алырбыз да керербез.* А.Хәсәнов. *Ә Нурихан берәү дә бозарга кыймаган шул көйнең уптым илаһи бөтен кылларын умырып ташлады.* Н.Гыйматдинова; 2) Әштер-өштер генә, җиренә җиткереп түгел; төптән уйлап бетермичә. *Җиңел булмады аңа бу адымны ясавы. Уптым илаһи гына эшләнми андый адымнар.* М.Хәсәнов. *Ләкин болар, чынлап та, әллә ничек уптым илаһи эшләнгән. Аларга карап кеше соклану кичерми, йөрәгендә мәхәббәт тойгысы тумый гына түгел, әллә ниткән шәрә салкынлык, ятышсызлык сизә.* А.Вергазов

**УР** *и.* 1) Дошманнан саклану өчен, шәһәр яки кальга тирәли казып ясалган траншея. – *Әнә теге урларны күрәсеңме? – Юк. – Ул чокырлар – борынгы бабайларыбыз авылы, шуның эзләре.* Ә.Баян. *Сулы урларны һәм тирән чокырларны көч-хәл белән узып, берничә тапкыр диварга да үрмәләп карадылар.* З.Мәхмүди

2) Текә ярлы коры елга, тирән чокыр. *Андагы еланлы сазлыклар, урман*

*тавыгы оялары һәм төлке уйный торган урлар...* М.Мәһдиев. *Ерак урманнарда калган урлар Кызгылт төскә кереп чыланыр...* Р.Зәйдулла

3) *диал.* Ясалма инеш, канау. *Чишмәдән ерак та түгел ур суы ага.* Ә.Баян

**УРА** *ы.* 1) Сугышта һөҗүмгә күтәрелергә өндәү ораны. *Кемдер вал өстенә сикереп менде, автоматын болгап: – Ватан өчен! Ура! – дип кычкырды.* Г.Әпсәләмов. *Ләкин авылның ул очыннан дошман сугышчылары инде бәреп кергән һәм, ура кычкырып, күпергә якынлашып киләләр иде.* В.Нуруллин

2) Башлыча гаскәриләрнең, шулай ук башкаларның да нәрсәнедер хуплауларын, нәрсәгәдер соклануларын белдерү сүзе. *Музыка, аның сүзен бүлеп, шатлык көен уйнарга, колоннадагы эшчеләр, кызылармеецлар, хезмәткәрләр ура кычкырырга тотындылар.* А.Алиш. *Ишектән әлеге ак халатлы кыз атылып-бәрелеп керде дә бөтен палатага сөрән салды: – Фашист дөмекте, иптәшләр! Сталинград – безнеке, ул азат! – Ура!* Г.Гомәр

3) Куаныч, зур канәгатьлек хисләрен белдерү сүзе. *Телефоны сүнүгә, малай кычкырып ук җибәрде: – Ура! Минем Айрат абый кайткан. Машинасы белән.* З.Мурсиев. *Каян сизенгәндер Ирек: – Ура! Әнием кайтты! – дип кычкырды да ишеккә атылды.* В.Нуруллин

**УРАВЫЧ** I *с.* Әйләнеч, урау. *Алай да китәр алдыннан, туры юлны уравыч итеп, бер сугылып чыктым аның янына.* М.Маликова. *Хатын уравычрак сукмактан юл алды.* Ф.Җамалетдинова

**УРАВЫЧ** II *и. сөйл. к.* **чолгау**. *Гөлчәчәк апа Нуруллина, мәсәлән, бик сирәк әйберләр: әнисенең күкрәкчәсен һәм киявгә чыкканда иренә бүләк иткән чигүле балтыр уравычын, сандыгын алып килгән иде.* А.Сәйфетдинова

**УРАГА** *рәв. сөйл.* Зур уңыш белән, хуплау табып. *Жәүдәтнең аналитик журналист мие бер шәйне дә урага кабул итмәгән шикелле, миңа камил күренгән юлларда да ышандырып җитмәгән, җөе сүтелебрәк торган урынны тапты.* Т.Галиуллин. *Тәүге хикәяләрен, «Без – кырык беренче ел балалары»н, «Фронтовиклар»ын «Казан утлары»ның баш мөхәррирләре (Р.Мостафин, Г.Ахунов) күтәреп алып, тиз генә бастырып чыгарудан, укучының, тәнкыйтьнең урага кабул итүеннән «башы әйләнгән» Мәһдиев, пьесалары да шундый ук уңышка ирешер дип хыялланып, хәтта шулай булуына шикләнмичә, режиссёрларның, театр әһелләренең күңел ишекләренә «шакый» башлый.* Казан утлары

**УРАГЫЧ** I *с. к.* **уравыч** I. *Бер куанам, бер янам, театрга барып җиткәнче (ә мин урагыч юллардан, озак итеп, кибет витриналарына бага-бага бардым) мең төрле сорау әзерләп бетердем, тик шул мең арасында беренче соравым – акыллысы гына юк иде...* А.Гыйләҗев. *Салих төн уртасында торып утырып, таныш җирләр буйлап юл сызып карады. Әллә ни урагыч та түгел, була бит – уҗым, болынны бөтенләй диярлек таптамый үтәргә була.* Р.Төхфәтуллин

**УРАГЫЧ** II *и. махс.* Нәрсәне дә булса (киләпле җеп, тимерчыбык) урау, чорнау җайланмасы, машинасы. *Урагыч шүресе*

**УРАЗА** *и. фар.* 1) *дини* Ислам диненең биш шартыннан берсе булган, таң алдыннан алып кояш баеганчыга кадәр ашау, эчү һәм җенси мөнәсәбәтләрдән тыелып торудан гыйбарәт гыйбадәт. *Кемгәдер ураза – савап, Кемгәдер гаеп инде.* К.Булатова. *Моңа чаклы бер намазын, уразасын калдырмаган хатынның болай үзгәрүеннән шикләнделәр, акылына зәгыйфьлек килүдән курыктылар.* Р.Хәбибуллина

2) *сөйл.* Рамазан ае. *Ураза аенда без, малайлар, мәчет коймасы буена җыелып, аның [мәзиннең] кичке азан әйткәнен көтә идек.* Ә.Еники. *Берничә көннән бит ураза җитә.* Идел

3) Төрле диннәрдә гыйбадәт максаты белән, шартларын китереп, билгеле вакыт нәрсәләрдән дә булса тыелып тору (нәрсәләрдер ашау-эчүдән, гомумән ашаудан, сөйләшүдән һ.б.ш.). *Византиядә Константинополь шәһәре башлыгы христиан уразасы көннәрендә терлек маеннан сабын кайнатуны тыя, бу көннәрдә аны зәйтүн маеннан эшләгәннәр.* А.Тимергалин

4) *күч.* Күпмедер вакыт ашамый торырга, ач калырга мәҗбүр булу. *Ашау – бөек нәрсә ул: бигрәк тә бер тәүлек «уразадан» соң.* Ә.Еники

◊ **Ураза ачу** Вакыты җиткәч ифтар кылу, уразаны бозу; авыз ачу. *Шәйхи карт боларны бик кызгана: – Арыш белән бодай башы уып ашаганнан ураза ачылмый, – ди ул, халык янына килгәч. Иллә мәгәр инде тоз белән таракан җимешен авызга да алырга ярамый.* М.Мәһдиев. **Ураза бозу** Ниндидер сәбәп белән яки вакыты җиткәч ифтар кылу, авыз ачу. *Син, ни, капкаларга берәр нәрсә хәстәрли алмассыңмы? Менә уразаны бозарга иде исәп.* К.Кара. **Уразага керү** 1) Рамазан ае башлану. *Атна-ун көннән уразага керәбез.* Н.Гыйматдинова; 2) Ураза тота башлау. *Уразага кереп, әбкәм Хәлсезләнгән чакта, Әйтә идем: – Әбекәем, Саулыгыңны сакла.* Г.Морат. **Ураза тоту** 1) Ураза гыйбадәтен үтәү. *Карт-коры июньнең озын көнендә ураза тотып җәфа чиккән вакыт иде.* М.Мәһдиев. *Рамазан ае бит, әти. Бер генә көн ураза тотсаң да яхшы булыр иде сана.* Р.Зәйдулла; 2) Күпмедер вакыт ач калырга, озак ашамыйча торырга мәҗбүр булу. *Бер атна, яки бер ай гына булса икән, әйтергә генә ансат: тиздән ике ел була... Тагын кайчанга хәтле ураза тотарга кушасыз, җан кисәгем? Мин дә бит кеше.* Ф.Хөсни

**УРАЗА́ БӘЙРӘМЕ** *и. дини к.* **Ураза гаете**. *Ураза бәйрәме көнне Казанга ук барып гает намазы укып кайтучы бер карт белән таныштым.* А.Тимергалин. *Ярар, Ураза бәйрәме алдыннан бераз дөнья күреп кайтсын...* А.Хәлим

**УРАЗА́ ГАЕТЕ** *и. дини* Ислам динендә рамазан аеның утыз көнлек уразасы беткәннән соң үткәрелә торган дини бәйрәм; Рамазан бәйрәме. (Корбан бәйрәме белән беррәттән, мөселманнарның иң зур бәйрәме). *«Әти! Ураза гаете еракмы?» – диярга башымны күтәрдем.* Г.Исхакый. *[Сәгъдетдин:] Бүген ни бит, Ураза гаете... Бәйрәм... Без мөселманнар, ни инде, теге...* А.Гыйләҗев

**УРАЗАЛЫ** *с.* **1.** Ураза тоткан, уразада булган. *Урамнарга, тыкрыкларга эңгер-меңгер иңә башлады. Азан һаман юк та юк. Уразалы кешеләр әле бу капкадан, әле икенчесеннән башларын сузып безгә карыйлар.* Г.Бәширов. *Гүя басудан сусап-көеп, йөзеннән кисәк-кисәк кояш көекләре коелып кайткан уразалы Миңсылу, калхузчы Миңсылу түгел, ә бәлки, Айдан төшкән Зөһрә кыз!* А.Хәлим

**2.** *и. мәгъ.* Ураза тотучы кеше. *Бу уңайдан Пәйгамбәребез (с.г.в.) болай дигән: «Уразалының уразасын ачканда кылынган догасы кире кайтарылмас».* Дога китабы

**УРАЗАСЫЗ** *с.* **1.** Ураза тотмаган, уразада булмаган. *Әмма кемнең халык алдында «уразасыз» дигән яманатын чыгарасы килсен?* Г.Бәширов. *Чөнки, билгеле булганча, һәр бәйрәмнең мәҗлес түрендә утыручы үз герой-*

*лары була, гадәттә, күпчелек тәшкил итә торган урталары була, шулай ук ишек төбеннән уза алмаганнары да, ишекнең тышкы ягында ук калганнары да, хәтта, искечәрәк итеп әйтсәк, гает көнне «мәчет астына» ябылырга тиешле намаз-ниязсыз, уразасыз гөнаһ ияләре дә була.* М.Әмир

**2.** *рәв. мәгъ.* Уразага кермичә, ураза тотмыйча. *Берәрегез чирләсә яки сәфәр чыкса, соңыннан уразасыз узган көннәр өчен башка көннәрдә тотып бетерер.* Безнең гәҗит

**3.** *и. мәгъ.* Ураза тотмаучы кеше. *Уразасызларга карата хәтта ниндидер җәмәгать фикере урнаштыру, тәнкыйтьләү кебек нәрсә дә сизелә иде.* Г.Бәширов

**УРАЙ** *и. иск. кит.* Нәрсәнеңдер юлын бүлү өчен аркылыга казылган чокыр, канау; *русчасы:* **перекоп**. *--- ләкин урай – хәрби объект булган, моны төрле төбәкләрдәге урай – «нығытма, кальга» мәгънәсендәге топонимнар күрсәтә.* Р.Әхмәтьянов

**УРАЙЛАТЫП** *рәв. диал.* Коеп һәм уратып-уратып, давыллап. *Урайлатып яңгыр яуды бүген, Мул чылатып үтте басуны. --- Хәзер яумый урайлатып, Пыскый эчне пошырып.* К.Булатова

**УРАК** *и.* 1) Агач саптан һәм ярымай формасындагы, вак тешле йөзле пычактан гыйбарәт кул белән иген ура торган авыл хуҗалыгы коралы. *Аерма тик шунда: алар хәзер элекке төсле үгезләр җиккән арбаларда түгел, дәһшәтле ут арбаларында кайталар; кылычлар, сөңгеләр, уклар белән коралланып түгел, сабаннар, ураклар, чалгылар, балталар белән коралланып баралар.* Гали Рәхим. *Әбекәйнең кул җылысын тоеп, Урак сабын кысам учыма...* Р.Низамиев

2) Иген уру эше. *Арыш урагының беренче атнасында ук Җиһан өмә җыярга булды.* М.Галәү. *Иртәгә уракка төшәбез, дигән көнне яшьләр кичке уенга көлтәләр күтәреп чыгалар.* А.Гыйләҗев

3) Иген уру вакыты. *Сиңа, бәбекәем, арыш урагы җитсә, ун тула инде...* М.Мәһдиев

◊ **Урак өсте** 1) Иген уру вакыты. *Икенче җәйне, урак өсте алдыннан Мирвәли аерата тилереп, шашынып китте.* А.Гыйләҗев. *Әле авылда печән өсте тәмамланмаган, урак өсте башланмаган чагыштырмача бер тыныч аралык.* А.Хәлим; 2) Урак уручылар. *Менә бервакыт бөтен урак өсте безне карарга җыела.* Г.Минский. *Урак өсте вәкиленнән эшче сыйныф вәкиленә шулай әйләнде ул.* М.Хуҗин; 3) Кызу, ашыгыч эш. *Хәзер бит институтта урак өсте, курстан курска күчүне хәл итә торган язгы зачётлар.* И.Салахов. *Мин яланаяк кына, чалбар балакларын сызганып идән юып маташа идем ---. – Сездә урак өсте икән, – диде ул [Арзу]. – Сугыш заманасының һәр көне урак өсте дисең бит үзең!* А.Гыйләҗев

**УРА́К БӨҖӘГЕ** *и. зоол.* Чын цикадалар семьялыгыннан үзенә генә хас чырылдау тавышы чыгара торган үтәкүренмәле канатлы сикерүчән бөҗәк; цикада

**УРА́К МАШИНАСЫ** *и. к.* **ургыч**. *Ә монда челлә эссесе. Ә монда бабай, урак машинасы. Машинага җигелгән атлар.* Р.Батулла. *Колхоз кырындагы урак машиналарының бер күтәрелеп, бер төшеп әйләнгән канатлары, тезелеп урак урып барган колхозчылар гүя ул ялгыз бүрене урманга куып баралар төсле.* Һ.Такташ

**УРА́К УРУ** *ф.* Урак ярдәмендә иген уру. *Яшь баласы булса, баланы кабык арбага салып, тәпи киткәннәрен – тәпиләтеп, үзләре белән алып, хатыннар кырда урак урдылар.* Д.Каюмова. *Анысы, мин дә урак урганда да сине генә уйлыйм.* А.Әхмәтгалиева

**УРА́К УРУЧЫ** *и. к.* **уракчы**. *Вә шуларга ялганып чалгы кайраулар, кыҗырт-кыҗырт киселгән урак тавышлары, арба астыннан ишетелгән яшь оланнар еглавы табигатькә бер тулылык биреп торсалар да, эсседән күгәреп беткән ираннәрне җебетерлек, юешләтерлек бер тамчы да су булмаганга, урак уручыларның хәлләре авыр, һәммәсе дә арып-йөдәп беткәннәр иде.* Х.Хәмидулла. *Әвендә эшләгән хатыннар, кесәләренә салып, өйләренә арыш яисә борчак алып төшмиме, урак уручылар басуда ут ягып таба белән бодай куырып ашамыйлармы, олаучылар арбаларына салам-печән салып кайтмыймы, басуда үсеп утырган игеннәргә кул сузучы юкмы?* Р.Фәизов

**УРАК-ЧҮКЕЧ** *и.* Эшчеләр белән крестьяннар дуслыгы билгесе буларак бергә кушып ясалган урак һәм чүкеч рәсеме – Советлар Союзы эмблемасы. *Урак-чүкеч төшкән орденым бар, Тырыш хезмәт өчен бирделәр.* И.Гыйләҗев. *Әнә урак-чүкечле байрак, демонстрация. Бәйрәмдә чыгып шул агымга кушылмасам да, кайтканнарын күрә идем.* Ш.Галиев

**УРАКЧЫ** *и.* Урак белән иген ура торган кеше. *Кырга уракчылар килеп беткәнгә юл буп-буш булса да, бөтен җир тулы халык иде.* Г.Исхакый. *Уракчылар көндезгә кайта башламаганнармы?* Г.Бәширов

**УРАЛМА** *и.* **1.** Спираль рәвешендә уралган нәрсә. *Бәхетләренә, лабораториядә моның өчен кирәкле җиһазлар барысы да әзер, чормада ниндидер бер олуг тәҗрибәдән соң файдаланылмыйча эшсез торган гаять зур бисоленоид-пушка да төзек, аны Кояшка төбәргә дә, элементар кисәкчекләр генераторына тоташтырып, беләк юанлыгы бакыр уралмаларына миллионнарча амперлы ток кына бирергә кирәк иде.* А.Тимергалин

**2.** *с. мәгъ.* Уралган формалы. *Уралма сабаклар нинди дә булса бер терәккә уралып үсәләр.* Ботаника. *Уралма көпшә*

**УРАЛМАЛЫ** *с.* Урап эшләнгән; уралма формасында булган. *Бакыр чыбыкның очында 5–6 уралмалы спираль ясагыз.* Органик химия

**УРАЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **урау**. *Ә безнең Яссы Алан гел юкә агачлары белән уралган.* Г.Галиева. *Илсур төшеп барышлый, бозавы янына килеп, аның казыкка уралган бавын сүтеп китте.* М.Яһудин

2) Нәрсәгә дә булса чорналу, сарылу. *Таш бәйләнгән бау, очып барып, әлеге агачка урала.* Г.Әпсәләмов. *Хәйдәр, бар дөньясын онытып, шомырт белән майкасын тутырганда, аста Миңнеханның йөрәк өзгеч тавышы яңгырады: – Ботакка елан уралган! Хәйдәр, җиргә сикер!* В.Имамов

3) Кемдер ниндидер озын, киң нәрсәгә чорналу, буталу. *Һади, халат итәгенә уралып, коридорга ташланды.* А.Гыйләҗев. *Җитмәсә, шинеле дә озын: атлаган саен, ашыккан саен чабуларына урала.* И.Салахов

4) Бик озын нәрсә үз тәртибен югалту, чуалу. *Аягына ниндидер түмгәкләр очрады, озын сабаклы үләннәр уралды, ә ул, әкияттәге Камыр батыр кебек, биш атлыйсын бер атлап, үз алдындагы караңгылыкка текәлгән көе, тәненең авырлыгын да тоймыйча, элдерде генә.* Н.Фәттах. *Хәл болай була: беренче тапкыр парашюттан сикергән Аликның һәм аның иптәшенең парашют җепләре урала.* Өмет

5) Күмелү, каплану, иңләп, чолгап алыну. *Зәлия, озын сигарет кабып,*

*төтенгә уралып килеп кердә.* А.Гыйләҗев. *– Куркак син, Әбләз! – диде Хәйрүш җитди генә һәм, караңгылыкка уралып, сыңар тәрәзгә таба китте.* Р.Зәйдулла

6) *күч.* Сарылу, кочаклап алу; ышкынып сырпалану. *Ир юмаланып муенына уралган хатынны диванга селтәп атты.* Н.Гыйматдинова. *Алабае шуны сизә бугай – Аягына килеп урала.* Ф.Мөслимова

7) *күч.* Кем яки нәрсә тирәсендә чуалу, берәр урында озаклап йөренү, булашу, әйләнү. *Айбиби үз балдагын апасына күрсәтте, шатланды, әле бер бармагына, әле икенче бармагына киде, кулларын әйләндереп, көзге алдында уралды.* М.Хәбибуллин. *Нечкә итеп кырылган мыегы астыннан сизелерсизелмәс кенә елмайган карт казан тирәсендә уралган карчыгына: – Син ничек, Садрикамал, каршы түгелсеңдер бит, нигәдер тавышың ишетелми монда? – дип эндәште.* З.Зәйнуллин

8) *күч.* Берәр кеше тирәсендә йөреп, аның эшенә комачаулау. *Салган бәрәңгеләр боз булып каткан. Эт кимереп караган, булдыра алмаган. Ваткалап биргән идем, ырылдап ташлана, азыгына якын җибәрми. Көт тә тор, тешләп үк алыр! Янында уралган көчеккә дә шулай.* Ш.Галиев. *Илдарга: иркә төпчек малайга гына җитмәде эш. Ул токмач баскан әнисе янында уралды.* Д.Булатова

9) *күч.* Нинди дә булса хәлгә дучар булу, берәр тойгы, кичереш тәэсирендә булу. *– Үләсең килсә, башка җирне сайла, – диде ул, Рөстәмнең беләгенә чат ябышкан кулын һаман җибәрмичә. – Минем ике балам бар. Бәлагә ураласым килми.* М.Кәбиров. *Арпадның үсмер еллары да бәхеткә уралмаган.* Шәһри Казан

**Урала бару** Торган саен һаман уралу. *Бу җылан әнисеннән туа бара икән, ди, ә үзе, тәрәздән тышка чыгып, өйгә урала бара икән, ди.* Әкият. *Бу мәлдә мин, әлеге сүзләрнең мәгънәсен аңлап ук бетермәсәм дә, үзәк өзгеч моңнарның, әниемнең уч төбендә бөтерелгән орчыктагы җеп сыман, йөрәгемә урала баруын тойдым.* М.Садыйков

**Урала башлау** Уралырга тотыну. *– Качып котыла алмассың, – дип, каһкаһә белән көлә-көлә, тәнемә урала башлый.* К.Кара

**Уралып алу** Тиз арада уралу

**Уралып бетү** Һәрьяктан уралу; тәмам уралу. *Улы Зәет, Нурия янына килеп, хан заманында ясалган, зәңгәр изоленталар белән уралып беткән телефонын алтын кошка тиңләп мактанып китте.* К.Кара. *Пускач бавы уралып беткән.* Р.Вәлиев

**Уралып йөрү** Озак вакыт уралу. *– Кил әле монда! – дип кычкырды ул күптәннән шушы тирәдә уралып йөргән күрексез киемле урыс малаена.* Т.Гарипова

**Уралып яту** *сөйл.* Уралган хәлдә булу. *Эш коралларын өләштеләр, эш урыннарына билгеләделәр, вагоннар буенда тезелеп утырган «Урал» пычкылары билгеле кешеләргә йөкләнде, агач эләктереп тарттырырга тәгаенләнгәннәр, уралып яткан тросларны бүлгәләп, чокерлар ясарга алындылар, балта, чылбыр ише нәрсәләр үткерләнде, җайланды, май, бензин савытлары тутырылды.* К.Кара

**УРАЛЫП** *рәв.* Бормаланып, борылмалар ясап; зур тизлек белән һәм болганып. *Агыйдел сулары булсам, Уралып агар идем.* Җыр. *Дим уралып акты, Идел ташты, Дулкын купты күлнең өстендә.* Р.Гатауллин

**УРАЛЫ́П-УРАЛЫП** *рәв. к.* **уралып**. *Юлчыларның алдында киң басулар уртасыннан, тулкын-тулкын барган сыртлар ашасыннан, дәрья кебек җәелеп, киң болыннар эченнән уралып-уралып аккан зур елга күренде.* Г.Ибраһимов

**УРАМ** I *и.* **1.** 1) Торак пунктта ике яклап рәттән тезелеп киткән йортлар арасында үтеп йөри торган аралык, пространство; араларында үтеп йөрү юлы булган өйләрнең ике рәте. *Әткәй, авыл урамы буйлап сөт җыеп бетергәч, машинасы белән район үзәгенә китәр.* А.Әхмәтгалиева. *Тукай урамында, трамвай тукталышы белән янәшә генә, аскы каты таштан, өскесе юан бүрәнәләрдән салынган җыйнак кына ике катлы йорт бар иде.* А.Хәсәнов

2) *җый. мәгъ. сөйл.* Шул ике рәтне тәшкил иткән йортларда яшәүчеләр. *Болай да бөтен урам синең урам себерүче икәнеңне белә.* А.Гыйләҗев. *Сабир, бар урамны куркытып, вак-төяк малайларны кыйнап, үз кулында тотса да, Габдрәхимне үзенә буйсындыра алмады.* З.Зәйнуллин

3) Бинадан тыштагы урын, ачык һава; тыш. *Чабата кары эрегәнче, тизрәк урамга чыктык.* А.Гыйләҗев. *Сиринә белән Нәзир көтү каршысына чыктылар, урамда яңгыр басылган, һава сафланган.* Ф.Яруллин

4) Гаиләнең, җәмгыятьнең тәрбия тәэсиреннән мәхрүм тирәлек, мохит; һәртөрле бозыклык таралган мохит. *Урам кызы узды төнге урам буйлап, Нидер уйлап узды кебек, нидер уйлап.* Г.Морат. *«Сәләт» милләт яшьләрен урамның тискәре йогынтысыннан, төрле бозык күренешләрдән: эчкечелек, наркоманлык, зиначылыктан, җинаятьчелектән саклап калу --- максаты белән оештырылды.*Шәһри Казан

5) Изафәле тезмәләрдә килеп, «җәмгыятьнең түбән, мәдәниятсез катламы зәвыгын, ихтыяҗын канәгатьләндерә торган» мәгънәсен белдерү сүзе. *Соңгы елларда укучыны ялгыш юлдан алып китә торган әдәпсез урам әдәбияты барлыкка килде.* Н.Гыйматдинова

**2.** *с. мәгъ.* Ишегалдыныкы булмаган, урам (*1 мәгъ.*) белән бәйле булган. *Шулвакыт урам яктагы ян капка ачылып китте.* М.Яһудин. *Ләкин күзгә күренмәгән башка вак-төяк эшләр дә килеп чыкты: өй түбәсеннән ит чаба торган тагаракны төшерәсе, казларга ашарга чыгарып бирәсе, мунча ишегенең тупсасы купкан икән, аны кагасы, урам бакчаның читәнен төзәткәләп куясы булды.* Н.Яһудин

◊ **Урам баласы** Күп вакытын урамда үткәрә торган, тәрбиясез, караусыз, гадәттә ятим бала. *Мин бүген урам чатында корышып утырган ике урам баласын ияртеп килгән идем.* Һ.Такташ. *Урам баласы үстерәләр дә, аннары тегеләр исә үз балаларыннан ваз кичәләр.* Д.Салихов. **Урамга чыгарып ату** *к.* **урамга чыгарып ташлау**. *Нишләсен Солтанъяр, номенклатурный работникны урамга чыгарып атып булмый, кадрлар бүлеге мөдире итеп алды.* З.Мурсиев. **Урамга чыгарып ташлау** 1) Торак йорттан куып чыгару. *Мине дә, сине дә карт көнебездә урамга чыгарып ташлата бит! Һәммә этлек тик шул Фәхридә генә.* Г.Ибраһимов. *Әмма ул: – Ах, әле син шулаймы?.. Торасыңмы, юкмы? Хәзер сөйрәп урамга чыгарып ташлыйм бит! – дип ныклап ук ачуланырга керешкәч, җылы түшәктә яту бик-бик рәхәт булса да, тизрәк торудан башка чара калмады.* В.Нуруллин; 2) Яшәү мөмкинлекләреннән, эштән һәм эш хакыннан мәхрүм итү. *Мине бүген булмаса иртәгә эт урынына урамга чыгарып ташларлар, мин шунда дөмегермен.* А.Расих. **Урамда**

**калу** *к.* **урам уртасында калу**. *Алай да мине урамда калдырмаслар, үзләре барып баш төрткән җирләренә мине дә сыйдырырлар, дип көтте Казбек.* А.Хәсәнов. *Бер гаебем булмаган килеш, ник әле мин яраткан, белгән эшемнән китәргә, урамда калырга тиеш ди?!* Р.Габделхакова. **Урам йөртү** Элекке заманда зур җинаятьтә (бигрәк тә урлауда, уйнаш итүдә) гаепләнгән кешене урам буенча бөтен халыктан мәсхәрә иттереп йөртү гадәте. *Сарык тиресе ябындырып, чиләк кагып, урам йөртергә кирәк!* Г.Бәширов. *Әмма, йөзләренә кара ягып, урам йөртүләр булган.* М.Мәһдиев. **Урам кызы** 1) *к.* **урам баласы**; 2) Фахишә. *Чөнки теләсә кемгә ияреп китәргә әзер торган урам кызы түгел бит ул.* Р.Кәрами. **Урам малае** *к.* **урам баласы**. *Кичәге надан урам малае шул арада роман язарлык, педагогия институтына керерлек белем дә алып өлгергәнме?* М.Шабаев. **Урам себеркесе** Фахишә. *Әллә мине урам себеркесе дип белдегезме?* Ф.Яруллин. **Урам сүзе** 1) Тупас сүз, сүгенү сүзе. *Менә әле генә әйрән сатучы бер кыз үземне урам сүзләре белән сүгеп китте.* М.Галәү; 2) Гайбәт, имеш-мимеш. *Сабира аны кырт кисте: – Җә, кодагый, син дә инде, алтмыш яшькә җиткәнсең, урам сүзен телгә алып йөрисең, – диде.* Г.Ибраһимов. **Урам тастымалы** *к.* **урам себеркесе**. *[Җиһанша:] Ах, син, урам тастымалы, себерке, хәерче, исән чакта югал күземнән!* К.Тинчурин. **Урам теле** Әдәби телнең стилистик закончалыкларына җавап бирми торган сүзләр, гыйбарәләр кулланылган гади сөйләм. *Ул [Ә.Еники] инде сезгә урам теле белән, гәзит яисә радио-телевидение теле белән китаплар калыплаучы түгел. Ул – тел остасы!* Р.Миңнуллин. *[Мәүлидә:] Киемең юк, дусларың юк, телең – урам теле, эш сөймисең, нәрсәсе дөрес түгел?* Ю.Әминов. **Урам телендә** 1) Киң массаларга аңлаешлы, алынмалар, терминнар белән катлауландырылмаган телдә. *Дәхи дә, шундый бар кеше дә аңларлык, урам телендә булган китаплар насыйп булсын.* Г.Камал; 2) Халыкта, халык арасында. *Урам телендә аны Ярми карт дип йөртәләр.* Г.Ибраһимов. **Урам тутырып** 1) Бөтен урам киңлегенә. *Әнә башка заводларның да кешеләре, урам тутырып, шул якка таба баралар.* Ә.Еники. *Урам тутырып, эшчеләр эштән кайталар.* М.Хәбибуллин; 2) Бөтен урамга ишетерлек итеп, барлык кеше ишетерлек итеп. *[Мәүлидә:] Ә Миндар абыең? Ирем белән бутала дип, хатыны урам тутырып сине сөйләп йөри.* Ю.Әминов. *Усал эт өрә Урам тутырып! Аулаграк бугай Теге тыкырык...* Ш.Галиев. **Урам уртасында калу** 1) Тораксыз, тәрбиячесез калу. *Бер елның февралендә, бензин сибеп, өйне яндырды. --- Шулай итеп, кыш көне бернәрсәсез урам уртасында калдык.* Сөембикә; 2) Эштән, керемнән, яшәү өчен кирәк булган мөмкинлекләрдән мәхрүм калу. *Ул фирма бер-ике елдан соң сынганга, Шәмси тагы урам уртасында калды.* Г.Исхакый. **Урам хәбәре** Ышанычсыз хәбәр, имеш-мимеш. *Иң элек качкын телгә килде: – Тукта, иплән сөйлә әле... Урам хәбәрләре генә түгелме?* Г.Ибраһимов. *Соңгы вакытта «яшел елан» белән дуслашып китүе турында да урам хәбәрләре йөри.* С.Поварисов. **Урам эте** 1) Иясез эт. *Лампочкалы багана төбендә әвәрә килгән урам этләре дә, төнге аудан биһуш булып кайтып килгән җирән мәче дә, аяк астындагы карның тансык шыгырдавы да бу тынлыкны боза алмый.* В.Нуруллин. *Ишегалдындагы шаушуга бөтен урам эте уянды.* Г.Гыйльманов; 2) *тирг.* Абруйсыз, дәрәҗәсез кешене сүгеп ачулану сүзе. *[Фәрхи:] Кыямәт тә, ахырзаман да булыр... Әллә бу сугышларны тикмәгә дип торасыңмы?.. Барысы да – менә сезнең шикелле урам этләренең гөнаһ шомлыгы!..* К.Тинчурин. *Бер юанычы бар иде хатынның: менә улы буй тартсын әле, күрсәтер сиңа, урам эте!* Н.Гыйматдинова

**УРАМ** II *и.* Тигез итеп уралган, чорналган җеп, тимерчыбык һ.б. *Тимерчыбык урамы. Шпагат урамы. Бау урамы*

**УРАМА** *и.* 1) Озын полосалы әйбердән урап төрелгән төргәк; урам. *Бер читкә махсус җәйланмага клеёнка урамалары, парниклар өчен полиэтилен төргәкләре эленде.* Д.Булатова

2) Озын тукыма кисәгеннән чалма рәвешендә баш тирәли чалына торган баш киеме. *Нечкә билле, ука күкрәкле бишмәтләр кигән, ак урамалар ябынган ак чәчле, җыерчык битле, кайгылы күзле кимперләр, елап күзе кызарган киленчәкләр һәм шау-шулы җирне ярата торган сылу кызлар, ак тирмәләрнең берсеннән чыгып, берсенә кереп, нигәдер йөреп торалар.* Г.Ибраһимов. *Төрек гаскәриләренең урамалары*

3) *махс.* Майга, йомыркага баскан төче камырны 2–3 мм калынлыкта тасма итеп кисеп, кайнап торган майга салып пешереп әзерләгән чәчәк формасындагы чәй яны азыгы. *Бәби һәм бишек туйларында табында татлы ризыклар өстенлек алып тора: кунакларга чәй янына төрле төсләр белән бизәлеп әзерләнгән әлбә, татлы талкан, кәләвә, камырдан ясап пешерелгән роза чәчәге, урама, гөлбәнәк һәм башка төрле ашамлыклар тәкъдим ителә.* Ю.Әхмәтҗанов. *Көз җиткәч, безнең өйдә тагы да кызды эшләр: Дәү әнием пешерде кош теләре, бәлешләр, Бавырсак һәм урама – тәме чыкты урамга.* Р.Харис

**УРАМАВЫЗ** *и. сөйл.* Имеш-мимеш таратучы, сүз йөртүче, гайбәтче. *Авылда урамавызлар күп була. Колактан колакка чыш-пыш сүзләр әйтелә, тел очларыннан ул чыш-пыш гайбәт галәмәте булып чәчри дә Гыйрфан мулланың өй түренә менеп кунаклый.* С.Поварисов. *Килененңне әйтер идем. Урамавыз булды, һаман гайбәт сөйли, җирбит!* М.Әхмәтшина

**УРАМДАШ** *и.* Бер урамда яшәүчеләрнең һәрберсе. *Сабакташлар, урамдашлар Безнең турыдан үтте.* Э.Шәрифуллина. *Янгын машинасы килүгә, урамдашыбызның ялкын чолгап алган печән кибәне суга батырылып, ишегалдына таратылып ташланган иде инде.* М.Яһудин

**УРАМЛАНУ** *ф. сир.* Урам рәвешен алу. *Кечкенә, җыйнак балчык өйләре тау араларына урамланып сузылганнар.* А.Таһиров

**УРАН** *и. гр.* 1) Орбитасы Сатурн белән Нептун арасында булган, Кояштан санаганда җиденче планета. *Марстагы борынгы елга үзәннәре, Сатурн боҗрасындагы «кигилар», Уран белән Нептунның боҗралары, дисталәрчә яңа иярченнәр һ.б. кебек ачышларны ябып куярга, мәктәп дәреслекләреннән алып ташларга кирәк була!* А.Тимергалин. *– Менә болары – Юпитер, Сатурн, Уран, Нептун планеталары, – дип дәвам итте сүзен Тим.* З.Мәхмүди

2) Көмеш ак төсле радиоактив металл, химик элемент. *Уранны җимереп тапкан бу радиоактив матдәләр туфракта һәм суда мең биш йөз ел яшиләр.* Ф.Бәйрәмова. *Җир кабыгы ярыкларына магманың агып керүе алмаз, сирәк металлар, мәсәлән, уран рудалары хасил булуга китергән.* Материклар һәм океаннар географиясе

**УРАНУ** *ф.* 1) *кайт. юн. к.* **урау**. *Пишкадәм, куркып, тиз генә юрганына*

*ранды, рәнҗүле тавыш белән зарланырга кереште.* Г.Мөхәммәдова. *Шулчак ишек ачылды, ап-ак мамык шәлгә уранган, ак пирчәткә кигән түгәрәк кенә кыз килеп керде.* А.Гыйләҗев

2) *ялг. к.* **уралу** (*6, 7 мәгъ.*). *Тик, ак төтен, үтә күренмәле шәүлә тукталып калмады, нәрсәдер эзләгәндәй, һаман шул тирәдә уранды.* З.Мурсиев. *Озак уранды олы йорт тирәли, сарык буган бүре кебек шашты, күзенә ак-кара күренмәде.* Р.Камал

**Урана бару** Торган саен ныграк урану

**Урана башлау** Уранырга тотыну. *Автобус эче шулкадәр суынды ки, әбиләр, калтыранып, үзләре белән алган бишмәт-пальтоларына, мамык шәлләренә урана башладылар.* Ф.Бәйрәмова. *Ак каеннар яшел яулыкларына урана башлаган, җир өстенә хәтфә үлән башын төрткән, зәңгәр күк йөзендә кояш кичкә авышкан.* Кызыл таң

**Урана төшү** Бераз гына урану; тагын да ныграк урану. – *Миңа калгач, шулай буласы билгеле инде... – диде Тәбрия һәм, куырылып, шәленә урана төште.* Ф.Җамалетдинова

**Уранып бетү** Тулысынча урану

**Уранып калу** Тиз арада, кинәт урану. *Мәмдүдә бусагадан атлап керүгә фәкыйрьлеккә уранып калды.* Р.Батулла

**Уранып кую** Тиз арада яки алдан урану. *Борчылмасыннар өчен генә, калын сырмасы белән билгә кадәр уранып куя, я аны, калын итеп бөкләп, астына сала.* Р.Рахман

**УРАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **урау**. *Стартка кузгалыр алдыннан, барча җайдакларны мәйдан буенча бер катураттылар.* В.Имамов. *Башын марля белән уратып бәйләгән, өстеннән җете кызыл кәләпүш чәпәгән, чалбар балакларын кирза итекләренә кыстырып кигән, кашларыннан цемент, төзелеш тузаны коелып торган бу кеше, көтмәгәндә, үз ихатасында, аңардан өч-дүрт адымда гына басып торган ят адәмне күреп туктап калды.* А.Хәлим

2) Чолгап алу, берәр кеше яки берәр нәрсә тирәсенә күпләп җыелу, туплану. *Бабай курайда уйнавын туктатты да үзен уратып баскан халыкны барлагандай карап чыкты.* З.Зәйнуллин

3) *к.* **урау** (*4, 5 мәгъ.*). *Әти: «Зәй аша барыйк, анда юл ышанычлы», – дигән иде, әни каршы төште: «Әллә кайдан уратып йөргәнче, турыдан гына чыгыйк», – ди.* А.Гыйләҗев. *Ни чүпрәк сатучылар, ни теләнчеләр бу яклардан уратмый, авыл бит урман белән күмелгән иде.* Н.Гыйматдинова

4) Нәрсәнең дә булса тирәсенә берәр нәрсә тоту; тирәләп, әйләндереп алу. *Шул мәйданны рәшәткәләр белән ураттылар, дистәләгән спорт җайланмалары булдырдылар, атна саен конкурсярышлар үткәреп мәш килделәр.* В.Имамов. *Бәләкәй генә өй салды да шуны биек коймa белән уратты.* Н.Гыйматдинова

◊ **Уратып сөйләү** Читләтеп, кинаяләп сөйләү, сүзне ерактан башлау. *Мин кыек-мыек, уратып сөйләп тормыйм инде.* З.Зәйнуллин. *Башка иптәшләре ничек җавап бирергә белмичә калтырап утырганда, ул иң беренче булып билет ала да уймак кадәр фикерне йомгак зурлыгында итеп уратып-уратып сөйләп ташлый иде.* Ф.Яруллин

**Урата башлау** Уратырга тотыну. *Машинист, идарә тизлеген көйләп, арканны урата башлады.* Ф.Зариф

**Урата төшү** Бераз урату; тагын да урату

**Уратып алу** Тулысынча урату; тиз арада урату. *Җәлпәк ботаклы нарат агачлары белән уратып алынган йорт янына җиткәч, сарыга буялган биек коймалар артында эт өргән тавышлар ишетелде.* А.Вергазов. *Күзләреннән яшь ага малкайның. Күз алкаларын – ак тоз элпәсе, бу элпәне чебен-черки уратып алган.* А.Хәлим. *Бөтен ягыннан да чәнечкеле биек коймалар белән уратып алынган.* В.Имамов

**Уратып кую** Алдан ук яки тиз арада урату. *Азнакайда, Сугышлыда, Шөгердә, Бөгелмәдә алмагачларны, куян кимермәсен өчен, юкә кабыгы белән уратып куялар иде...* Г.Әпсәләмов

**Уратып тору** Хәзер, әле урату; даими, һәрвакыт урату. *Изге калкулыкны тирә-яктан су боҗрасы уратып тора, су боҗрасыннан соң – җир боҗра, җир боҗрасыннан – тагын су боҗрасы.* Н.Фәттах

**Уратып чыгу** Булган бар җирне урату. *Ниһаять, бөтен коридорларны да уратып чыгып, әйлән-бәйләннең башы музыка уйнаган уку залына кереп барганда, койрыгы әле икенче катка гына якынлашып килә иде.* Х.Ширмән

**УРАУ** I *ф.* 1) Озын һәм нечкә яки тар нәрсәне дә булса берәр әйбер тирәли кат-кат әйләндереп чорнау. *Фәһимә орчыктан җепне йомгакларга урады.* Д.Каюмова. *Таһирҗан муенындагы кулъяулык-шарфын чишеп алды да моңсу гына утырган Гәүһәриянең муенына урады.* Г.Әдһәмова

2) Кемне яки нәрсәне дә булса әйбер белән бөтен яктан төрү. *Мине утка салыр өчен Одеалларга урадың, Әнкәй, инде үзең дә бит Кайгыларга уралдың.* Бәет. *Аларны [чучка малайларын] өч тапкыр һәр көн чишмә суы белән генә юып, щетиналарын тарап, Пакьстаннан килгән йөнтәс йомшак сөлгеләргә урап кына киптерделәр.* А.Гыйләҗев

3) *сөйл.* Тәмәкене, тарту өчен, кәгазь кисәгенә салып, көпшә формасында төрү. *Тәмәке урап кабыза да бер-бер артлы суыра.* З.Зәйнуллин

4) Кемне яки нәрсәне дә булса уртага алу, як-яктан камап, әйләндереп, чолгап алу

5) Эченә, үзенә кермичә яки янына ук килмичә, нәрсәнедер әйләнеп, читләтеп үтү. *Әмма Михельсон бу отрядны урап уза.* В.Имамов. *Ә инде нинди батыр йөрәкле булсалар да, егетләр мәктәп директоры Мифтахның йортын урап узарга мәҗбүр.* Д.Гыйсметдин

6) Нинди дә булса урынны берничә кат яки әйләнеч юл белән йөреп чыгу. *Туган авылым урамын Кабат-кабат урадым.* Г.Зәйнашева. *Гармун белән аю читтә торып торсын, аның белән җитәкләшеп урамны урап узулары гына да миңа искитмәле рәхәтлек бирә иде.* З.Мәхмүди

7) Каплау, томалау, үз эченә алу. *Шәһәремне алтын иген Дулкыннары ураган.* Р.Газизов. *Ә мине зур кайгы, тирән хәсрәт ураган.* А.Гыйләҗев. *Урады да кочагына Урлады сине буран.* Р.Миңнуллин

◊ **Урап кайту** 1) Каян да булса әйләнеп кайту, кая да булса барып кайту. *Бар, балам, урамнарны бер урап кайт әле син.* А.Мансуров; 2) Чит җирләрдә йөреп, ял итеп, гизеп яки эшләп кайту. *Бер елдан урап кайтты ул. Уң кулының баш һәм имән бармагы юк иде.* А.Хәлим; 3) Уйлап-уйлап та кабат баштагы ноктага, баштагы фикергә килү. *Уйлый торгач, уйлары берсе өстенә берсе боҗраланып, һаман да шул элеккеге фикергә урап кайта торган булдылар.* А.Хәлим

**Урап алу** Тиз арада урау. *Дивар өстендә лас-лос китереп орган чукмар, кылыч авазлары ат иярләрлек вакыт буе гына яңгырап торды да Рахман башкисәрләренең мәетләре каланы урап алган чокыр төбенә очты.* В.Има-

мов. *Германның авыр, кайнар гәүдәсе Ленизаны идәнгә кысып беркетте, гайрәтле куллары тәнен урап алды.* М.Маликова. *Башкортлар башлыкларын урап алдылар, нидер киңәштеләр бугай.* Ж.Рәхимов.

**Урап йөрү** Озак вакыт дәвамында урау; хәзер, әле урау. *Шомбыт кибетләрен урап йөреп, кабат чиркәү тавын йөгереп менеп соңга калган көннәрнең берендә, укытучының түземлеге бетте.* Н.Гариф

**Урап чыгу** Башыннан ахырына кадәр урау, бөтен ягында да булу. *Әле быелгы җәй уртасында гына бастырып куйган алачык тирәли ничәмә-ничә кабат урап чыкты инде.* В.Имамов

**Урый бару** Торган саен ныграк урау. *Үзем чабам, хыял болыты мине һаман да тыгызрак урый бара...* А.Гыйләҗев

**Урый башлау** Урарга тотыну. *Юк йомышларын бар итеп, цехның кызлары да яныннан ешрак урый башладылар.* Н.Әхмәдиев

**УРА́У** II *с. к.* **әйләнеч**. *Юлларың бик озак, Бик урау, бормалы.* Р.Тимерова. *Урман читенә җитәрәк, урау сукмакны кистереп чыгарга булды кызлар.* Л.Зөлкарнәй

**УРА́У** III *и.* Спираль яки винтсыман сызыкның бер әйләнеше

**УРАУЛЫ** *с.* 1) *к.* **әйләнеч**. *Урауль шул, бигрәк урауль Тарихларда калган юлыбыз.* Р.Әхмәтҗанов. *Бу тормышның юллары Урауль һәм катлаулы.* Р.Зәкуан

2) Билгеле санда уравы (III) булган. *Мәһабәт гәүдәле, чибәр, таза вә сәламәт Мотыйгулла хәзрәт башына йөз урауль ефәк чалма киеп йөри.* Р.Батулла. *Шунда гына хатын мине тавышымнан танып, урауль башыма ишарә итеп: – Карале, әтисе, синең сукыр эчәгең башыңда идемени соң? – диде.* Казан утлары

3) *күч.* Катлаулы; буталчык. *Җөмләләр кыска. Урауль мәгънә аңлата торган җөмләләр бөтенләй юк.* Г.Ибраһимов

**УРАУЛЫК** *и. сир.* Урап үтелгән ара, әйләнеч юл. *Кодалар алты-җиде чакрым урауыкны исәпләделәр.* Г.Ибраһимов

**УРБАНИЗА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Шәһәрләр саны арту процессы һәм дәүләтләрнең сәяси, икътисади һәм мәдәни тормышының шуларда туплануы. *Шуларның иң мөһимнәре дип түбәндәгеләрне атарга буладыр: бөтен цивилизацияле илләр өчен дә хас булган урбанизация, ягъни авыл халкының шәһәргә күченүе.* И.Хуҗин. *Урбанизация процессы көчәя, рус шәһәрләрендә татарлар ишәя...* Р.Вәлиев

2) Авыл тормышына хас нәрсәгә дә булса шәһәр тормышына хас үзенчәлекләр, сыйфатлар бирү. *Авылның урбанизациясе. Авыл тормышында урбанизация билгеләре*

**УРБАНИЗМ** *и. лат.* 1) Сәнгатьтә һәм әдәбиятта хәзерге зур шәһәр тормышын сурәтләү һәм тасвирлау күренеше. *Икенче яктан, тегe яки бу күләмдә Шәрык традицияләрендә тәрбияләнгән, хатын-кыз матурлыгын һәм табигатьне үтә сак мактауга гадәтләнгән, гөлчәчәк, сандугач, ал таң, былбыл кебек традицион сурәтләргә ияләнгән укучыларга Уитмен шигырьләрендәге ачыктан-ачык бәдәни мотивлар, көчле урбанизм, тән культы артык кыю һәм сәер тоелырга мөмкин.* Р.Мостафин. *Рәсем сәнгатендәге урбанизм. Бу әсәргә урбанизм хас*

2) XX гасыр шәһәр төзелешендә зур биналы гигант шәһәрләр булдыруны котылгысыз юл дип санаган юнәлеш. *Урбанизм идеяләре. Урбанизм стилендәге бина*

3) Халыкның күплегенә һәм шәһәр субкультурасына бәйле булган шәһәр халкына хас нормалар һәм әдәп кагыйдәләре җыелмасы

4) Автомобильле шәһәргә капма-каршы буларак кечкенә җәяүлеләр шәһәре (яки районы) булдыруны күздә тоткан шәһәр төзелеше концепциясе

**УРБАНИСТ** *и. лат.* Урбанизм тарафдары. *– Безнең нәсел борын-борыннан зур калаларда гомер сөргән, – дип дәвам итте Лариса. – Урбанистлар каны ага миндә. Кан калага тарта, димәк.* М.Маликова

**УРБАНИ́СТИК** *с.* Урбанизмга хас, урбанизмга бәйләнешле, урбанизм билгеләре булган. *Шулай да Р.Мингалимне урбанистик поэзия тарафдары итеп бәяләү дөрес булмас иде.* Т.Галиуллин. *Урбанистик бина*

**УРБАНИ́СТИКА** *и. рус* Икътисади географиянең шәһәр үзәкләренең эшләве һәм үсеше белән бәйле мәсьәләләрне өйрәнү һәм комплекслы анализ ясау белән шөгыльләнә торган тармагы. *Бүген, 8 нче июльдә, сәгать 13.00 тә, бәйрәмдә балалар өчен урбанистика, экология һәм архитектура өлкәсендәге экспертлар лекцияләр һәм белем бирә торган уеннар үткәрә.* Шәһри Казан

**УРБАНИСТЛЫК** *и.* 1) Урбанист булу

2) *к.* **урбанизм**

**УРГУ** *ф. сөйл. к.* **ургылу**. *Яшь гомердәй җирдән яшел чишмә ургый, кырда безнең хисләр кебек серкә уйный.* К.Сибгатуллин. *Уем белән һәрчак, дуслар, Мин сезнең янығызда. Ургыган чишмә булсамчы Сусаган җаныгызга!* Ф.Дәүләтбаев

**Ургый башлау** Ургырга тотыну. *Ә менә яз һәм көз көннәрендә минем иҗат чишмәм ургый башлый.* И.Юзеев. *Берзаман курай тишекләреннән төтен ургый башлый.* Р.Батулла

**Ургып тору** Даими, гел ургу; хәзер, әле ургу. *Хәйләкәрлек белән мәкерлелек агулары синнән тау чишмәсе кебек ургып тора.* В.Имамов

**УРГЫЛ** *и.* **1.** Елганың томырылып, ургып, кызу аккан урыны. *Әлеге чакырулы кичәдә шоңкар күзле Тансыкбаевның башына менә шундый уйлар килде, һәм --- ул, дәрьяның ургылына чумудан ләззәт алган оста йөзүче-гаувас сыман, арткannан-арта баручы дәртле омтылышлары һәм көчле теләкләре дулкынында тирбәлә иде.* Ч.Айтматов

**2.** *с. мәгъ.* Ургылып, уралып-уралып ага торган. *Тубыл елгасын уздык. Себер башланды. Иге-чиге булмаган тайга чытырманлыклары, яссы таулар, мул сулы ургыл елгалар.* М.Юныс

**УРГЫЛЛЫК** *и. диал. к.* **ургыл**

**УРГЫЛУ** *ф.* 1) Көчле агым белән, сикереп-сикереп, ташып-ташып агу. *Ә яңгыр һаман ява да ява, гөрләвекләр ташкын булып зур елгаларга ургыла.* И.Сираҗи. *Йомшак токымнарны елга акрынлап юа, ә юылуга бирешми торган каты токымнарның өскә чыккан өемнәре бусагалар барлыкка китерә. Алар аша үткәндә, су ургылып ага һәм күбекләнә, су тамчылары биеккә чәчри, су өермәләре барлыкка килә.* Башлангыч география курсы

2) Көчле басым белән бәреп чыгу. *Нефтьчеләр Олы су башында, Карама куышта, ике җәй яттылар, нефтьләре чыкмаган, казыган тишекләреннән ачы су ургылып ага, ди.* А.Гыйләҗев. *Аннары, ул тоннель әнә тегендә генә, дөрес, авызында таш җимерелгән, ләкин елга күтәрелгән вакытларда, ул тишек аша су ургылып агып чыгып тора.* З.Мурсиев

3) Тоташ агым булып уралып-уралып керү, чыгу, исү, күтәрелү. *Күккә ялкын ургыла, төтен күтәрелә,*

*як-якка очкыннар чәчри.* Р.Кәрами. *Һәй, качып кына мичкә чи утын ягалармыни: төтене барыбер моржадан өскә ургыла.* Н.Гыйматдинова

4) *күч.* Омтылу, ашкыну, ургу. *Күңелемдә хисләр ургыла да Чиртә башлый нечкә кылына.* Н.Әхмәдиев. *Салават тезгенен кагып куюга, ак бия язгы ташкындай алга ургылды, чегән балалары, чинашып, балаганга кереп качтылар.* Җ.Мостафин

**Ургыла башлау** Ургылырга тотыну. *Ә бермәлне инде яу кырын ташлап качкан ростовлылар Суздаль каекларына ургыла башлады.* В.Имамов

**Ургылып тору** Озак вакыт дәвамында ургылу; әле, хәзер ургылу. *Ике көн буе әнә шул трубадан нефть катыш су ургылып торды.* М.Хәбибуллин

**УРГЫЧ** *и.* Иген ура торган машина. *Ә басулар соңгы елларда бик нык үзгәрде. Комбайннар да, тракторлар да, ургычлар да без күреп үскәндәге түгел инде.* Р.Миңнуллин. *Җир чыгуга, чәчкечеңне кара, Ургычыңны көйлә аннары.* К.Булатова // Шул машинаның кисә торган өлеше

**УРДА** *и. тар.* 1) Урта гасырларда башында хан торган дәүләтнең башкаласы, шулай ук ханның тирмәсе корылган ставка. *Казаяклар өчен Күгән би үз урдасында киез өйләр кордырды, казан асарга дип, бер көтү сарык бирде.* Н.Фәттах. *Беркөнне Олы хан урдасыннан килгән чапкын хәбәрче ыру халкына мөһим сүз ирештергән: «Кем дә кем хан кызын үзенә хатын итеп алырга тели, шул кеше, мәйданга чыгып, бер чакрым ераклыкта йөргән кыр үрдәген атып алырга тиеш».* Г.Гыйльманов

2) Урта гасырларда башында хан торган эре феодаль дәүләт яки күчмә кабиләләр берләшмәсе. *Нугай урдасы халкы Иделдә һәм Көньяк Уралда XI–XII гасырлардан бирле яшәгән кырык угыз, каңлы, кыпчак кабиләләрен дә берләштергән төрки-татарлардан оешкан.* И.Хуҗин. *Шуңа күрә татарларның бу җирләрдә төрле дәүләтләр оештырып, әле кодрәтле каганатлар, әле Ак Урдалар, әле Күк Урдалар, әле Алтын Урдалар, төрле ханлыклар төзеп яшәүләре бер дә гаҗәп түгел!* Ф.Бәйрәмова

3) *иск.* Гаскәр, армия. *Сансыз татар урдам бар, Алтын егач тәхетем бар.* Дастан

**УРДАЛЫ** *с.* **1.** 1) Урдада яшәүче, урда вәкиле булган. *Күптән түгел М.Әхмәтҗанов тапкан гәйнә төркеменең бабалары күрсәтелгән шәҗәрәдән күренгәнчә, алар Аксак Тимер Болгарны җимергән дәвердә (XIV йөз ахырында) Биләр шәһәреннән күчкәннәр, кабиләләре буенча боркыт булганнар, ягъни Алтын Урдалы татарлар булып санала алалар.* Д.Исхаков

2) *иск.* Урдасы, зур гаскәре булган

3) *күч. иск.* Химаясе, яклар көче булган. *Урдалы елан белән уйнама.* Әйтем

**2.** *и. мәгъ.* Урда кешесе, урда вәкиле. *Урдалылар беренче ыргымда ук өстенлекне үз кулларына алды.* М.Әмирхан. *Мишәрне хәзәргә яки угызга ялгау, кыпчак, урдалы итеп күрү дә бар.* Безнең гәҗит

**УРДАЧЫ** *и* Урдачылык тарафдары

**УРДАЧЫЛЫК** *и.* Татар халкының этнос булып формалашуын Алтын Урда чорында күчмә монгол-татарларның Көнчыгыш Европага күчеп кыпчаклар белән кушылу һәм ислам динен кабул итү нәтиҗәсе итеп карау яклы булган фәнни-иҗтимагый агым. *Казан тарихчылары егерме еллар элек, урдачылыкка авышып, болгари тарихтан бизде.* Г.Нур

**УРДУ** *и.* Һинд-Европа телләр семьясына кергән, фарсы теленең зур йогынтысын кичергән Пакьстанның дәүләт теле, шулай ук Һиндстанның рәсми телләреннән берсе. *Таҗик, үзбәк, гарәп, фарсы, урду, пушту, рус, татар телләрендә аралашучы ошбу дин кардәшебезне үзебездә төпләндереп калдырырга иде бит.* Г.Гомәр. *Атасы Пакьстанда илчелектә эшләгәндә, шунда күчеп барып, урду телен өйрәнгән.* Т.Әйди

**УРДУЧА** *рәв.* Урду телендә. *Дәреслекләр нигездә инглизчә һәм урдуча язылa.* Ватаным Татарстан

**УРДЫК** *и. диал. к.* **сәке**. *Татарларның традицион йортларының эчке ягында калын такталардан эшләнгән, идәннән ярты метр биеклектәге агач ятак, шул ук вакытта, өстәл булып та хезмәт итә. Казан татарлары аны сәке дип атый, татар мишәрләре урдык дип йөртә.* Гали Рәхим

**УРДЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **уру**. *Балдыз, урак өсте җитә бит, шуңарчы кодача терелмәсә, ни кылырбыз, дим? Арышыңны кем урыр? Кешедән урдырсаң, ун поттан ким алмаслар.* К.Тинчурин. *Утырып калган игенне, кар төшкәч тә, хатын-кызны ялангa куып чыгарып, урак белән урдырдылар.* З.Зәйнуллин

2) *к.* **уру** (*1 мәгъ.*). *Тик хәзер инде монда башка малайлар урак урдыра...* Р.Миңнуллин. *Комбайнда Әти иген урдыра. Ул – алдынгы, һич ял белми, Иптәшләрен уздыра.* З.Мурсиев

**Урдыра башлау** Урдырырга тотыну. *Бүген, улым, бодай урдыра башлыйбыз, дип китте.* М.Хуҗин

**Урдырып бетерү** Тулысынча урдыру. *Көз җитеп, каты кыраулар да ешая башлагач, ул, тарым әрәм булыр дип куркып, тиз арада урдырып бетерү өчен, кәҗә бәрәнен суйган да өмә ясаган.* Г.Ибраһимов

**Урдырып карау** Сынау, белү өчен урдыру. *– Алар безгә килеп урдырып карасыннар шул хәтле, аннан сөйләшербез, – дигән иде.* Т.Миңнуллин

**Урдырып чыгу** Беткәнче, тулысынча урдыру. *Сүзенең азагында авыл хуҗалыгы идарәсе җитәкчесе басу читләрен урдырып чыгу зарурлыгы турында искәртте.* Биектау хәбәрләре

**УРЕМИЯ** *и. гр. мед.* Бөерләрнең аксым алмашы продуктларын һәм башка кайбер матдәләрне сидек белән чыгара алмау нәтиҗәсендә организмның кискен яки хроник агулануы. *Ми шеше тукталса да, уремиягә каршы чаралар күрүгә дә карамастан, беркадәр вакыттан соң Юматшаның канындагы азот калдыгы куркыныч рәвештә үсә башлады.* Г.Әпсәләмов. *Беренче тапкыр уремия белән авырган кешегә дуңгыз бөерен күчереп утырталар.* Кызыл таң

**УРКЫЛЛЫК** *и.* Утлап йөргән атларны тоту өчен бер башы элмәкле бау яки колга; корык. *Уркыллыгы булса, атын табарбыз.* Мәкаль

**УРЛАТУ** *ф. йөкл. юн. к.* **урлау**. *Җаваплылык зур шул – хөкүмәт акчасы. Урлатсаң, гомереңжитмәс түләргә.* А.Хәмзин. *Фермадагы өч үгезне урлатканнан соң, элеккеге каравылчы Мирхәйдәр кечкенә гәүдәле чәңгелдек этенең муенына таш бәйләп су астына җибәрде дә каладан зур овчарка сатып алып кайтты.* З.Хөснияр

**Урлата язу** Чак урлатмый калу

**Урлатып бетерү** Булган берсен урлату. *Барыбер урлатып бетерәсез дип, безнең ихтыяҗларга дигән акчаны «кыса» башламагайлары, дигән куркыныч бар, ахры.* Безнең гәҗит

**Урлатып тору** Әледән-әле урлату

**Урлатып яту** *сөйл.* Күрәләтә яки тыю мөмкин була торып урлату. *Син нәрсә, Мәүләви, ди, дәүләт утынын урлатып ятасың анда, ди.* Г.Кашапов

**УРЛА́У** *ф.* 1) Нәрсәне дә булса рөхсәтсез һәм яшерен рәвештә алу, үзләштерү. *Менә Сәмигулла абзый таягын ишегалдында калдырган. Синең малаең шуны урлаган.* А.Гыйләҗев. *Җитмәсә, юлга дип алган азыгын беренче көнне үк төенчеге-ние белән урладылар.* А.Хәлим

2) Кызны качырып алып китеп, туйсыз гына өйләнү. *Шулай бер ай үтте, ике ай үтте. Кызны урларга һаман җай юк бит. Саклыйлармы-саклыйлар.* А.Шамов. *Ләкин шунысын тәгаен әйтә алам: минем белән әнә шул «сөйләшүдән» соң ике көн үтүгә, Габдулла Халисәне урлап алып кайткан, һәм алар, язылышып, бергә тора башлаганнар иде.* В.Нуруллин

**Урлап бетерү** Булган берсен урлау, берни дә калдырмау. *Ул акчаның яртысын барыбер урлап бетерәчәкләр.* З.Хәким

**Урлап карау** Сынау максаты белән урлау, урларга тырышу. *Шундый заман килде: берәүләр ачтан үлә, икенчеләр урлап карый, тотыла, аны кыйнап үтерәләр.* Л.Гыймадиева

**Урлап тору** Әледән-әле, даимән урлау. *Елкылдап торган кызгылт сары озын йомшак йоны (кешеләр аның туып торган бөтен балаларын шул матур йоны өчен урлап торалар бит) йолкынып беткән.* Ә.Әминев

**Урлый башлау** Урларга тотыну. *Бу юлы инде Нарул белән Фидрат икәүләп, Иншар өйрәтүе буенча, кибеттән тегене-моны урлый башладылар.* З.Мурсиев

**Урлый бирү** Бернигә дә карамастан урлау эшен дәвам итү. *Кыз урлауны Совет власте декретлары белән үк тыйды. Ә егетләр күзләре төшкән чибәркәйне барыбер урлый бирәләр.* А.Хәсәнов

**Урлый язу** Чак урламый калу. *Сине бала чакта да урлый язганнар иде.* Г.Гыйльманов

**УРЛАШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **урлау**. *Имеш, никрутлар урлыйлар, бөлдерәләр, мин бит, аларга кушылып урлашырга иде, димәдем.* Г.Ибраһимов. *Ләкин аның да иманы юк икәнлеге көн кебек ачык: юньле бәндә кешегә кыз урлашырга риза буламыни?* В.Нуруллин

2) Караклык, угрылык белән шөгыльләнү. *Карак шайкаларына кушылып урлаштым да, сугыштым да, кеше таларга да туры килде.* Р.Мостафин. *Ә Усман авылы шул ук тормыш белән яшәде: ирләр эчте, хатыннары чирләшкә, зәгыйфь балалар тапты, егет-җилән эчү генә түгел, наркотик тәмли башлады, сугышты, кызларны бозды; бала-чага юньләп укымады, дәресләреннән качты, тәмәке тартты, урлашты.* Ә.Әминев

**Урлаша башлау** Урлашырга тотыну. *Бер урлаша башлагач, ташлап булмый.* З.Хөсния

**Урлашып йөрү** Гел, һәрвакыт урлашу. *Икенче яктан караганда, ни өчен хурланырга?! Урлашып йөрмәгән ләса.* З.Мурсиев

**Урлашып карау** Сынау максаты белән урлашу. – *Өйрәтер идем, минем дә урлашып караганым юк шул,* – *дип тыелып кына көлде Матильда.* К.Кара

**Урлашып тору** Әледән-әле урлашу

**УРМАН** *и.* 1) Зур мәйданда тоташ үсеп утырган агачлар, шулай ук күп булып агачлар үскән мәйдан. *Без аның белән урманга әллә җиләк, әллә гөмбә эзләргә барабыз.* А.Әхмәтгалиева. *Күрәсең, күптәннән урман эчләп тә үткәне юктыр: еш кына битенә агач ботаклары бәрелә, аны күрүгә, барлыюклы урман кошлары фырылдап очып китә.* Р.Кәрами

2) Төзелеш һәм сәнәгать материалы буларак киселгән агачлар; бүрәнәләр. *Тормыш йөген шундый кыенлык белән сөйрәп барганда, аңа тагын зур бәхетсезлек килә: урман агызуда эшләүче өлкән улы суга батып үлә.* Н.Ихсанов. *Элек синең ата-бабаларыңны тәртә арасына кертеп җиккәннәр дә әле. Зарланмаганнар, түзгәннәр. Җир сөргәннәр, урман ташыганнар.* З.Хөснияр

3) *күч.* Биек булып калкып торган күпсанлы әйберләр. *Өй түбәләрендә антенналар урманы...* Р.Хисмәтуллин. *Шәһәрләрнең барысының да бер уртаклыгы бар: таш йортлар урманы ешлыгында кешеләрнең күплеге.* Р.Батулла

◊ **Урман әүлиясы** Аңгыра яки беркатлы кеше турында. **Урман бите** Урман буе. *Син инде, хәзрәт, минем малайны берәр белеш баеңа урнаштыр инде, әгәр дә шул эш барып чыкса, урман битендәге арышыңны урып бирер идем.* К.Тинчурин. **Урманга утын ташу** Мәгънәсез эш эшләү. *Җәгърафия дә белмәсәң, кайдан нинди нәрсәләр чыкканын белмәсәң, урманга утын ташыган шикелле булса, итәрсең файда.* Г.Камал. **Урманга утын төяп бару** *к.* **урманга утын ташу**. **Урманга утын төяп килү** *к.* **урманга утын ташу**. *Кызның сораулы карашына җавап итеп бармак шартлатты да:* – *Урманга утын төяп килмиләр!* – *диде. Бу кинаяәнең мәгънәсен аңламаслык түгел иде.* Н.Гыйматдинова. **Урманда үскән** Үзен тота белмәгән, тәрбиясез кеше турында. *Яңгура куллларын юды һәм, һәр бармагын аерым-аерым сөртәсөртә:* – *Бу кыз урманда үскән кыргыймы әллә?* – *дип сорады.* Г.Әпсәләмов. **Урман итәге** Урман кырые, урманның күренеп торган ягы. *Әгәр шушында – билгесез урман итәгендә төн кунарга туры килсә?* Р.Низамиев. *Ул урам авылның төньягыннанрак, куе кара урман итәгеннәнрәк сузылып киткән.* С.Поварисов. **Урман иясе** Шүрәле. *Урман иясе атаклы Шүрәле дә бер мөгезле.* Г.Дәүләтшин. *Аннан питомник киртәсенең юан баганасы башына бер-ике җиләк куясың. Монысы – урман иясенә.* М.Мәһдиев. **Урман кебек (сыман, шикелле)** Бик куе, мул һәм биек булып күренгән әйберләр турында. *Бакчаларда йөзем. Кайберләрендә, урман шикелле кукрәп, кукуруз үсә.* Т.Әйди. --- *урыны-урыны белән үзен урман кебек басып киткән кырлы курай, ат кузгалагы, әче гөрләпәләр, тагын да әллә ниткән эт эчәкләре, билчән, кузаклы һәм кузаксыз, күзәнәкле һәм күзәнәксез үлән-үсемлек кыргыйлашкан халәттә гомер сөреп ята иде...* А.Хәлим. **Урман сарыгы** *к.* **урман иясе**. *Күпме генә арлы-бирле йөренсә дә, үрле-кырлы сикерсә дә, инеш суын атлап чыгарга батырчылык итми икән бу урман сарыгы.* Г.Гыйльманов

**УРМА́Н БЕТЕ** *и.* Талпан. *Тиктормас аю малаеның колак артларын урман бетләре басса кирәк.* А.Хәсәнов. *Ә инде карап туя алмаслык чибәр булып үсеп килүче Альбиналарын урман бете тешләп, баланың куллары хәрәкәтсез калгач, үзләре үк алтын таапкан көннәрен каһәрли башладылар...* Ш.Алпар

**УРМАНДАЛА** *и. геогр.* Төньяк ярымшарда урманнан далага, даладан урманга күчкән, урман белән дала аралашкан табигать зонасы. *Моннан биш-алты мең ел элек Евразиянең урмандала һәм далаларына көнбатыштан күпсанлы терлекче кабиләләр – һинд-европа халыклары таралалар.* Р.Әхмәтьянов

**УРМА́Н-ДАЛА** *җый. и.* Урманлы һәм далалы урыннар, урманнар һәм далалар. *Иң биек тауларның берсе булган Ирәмәлдән, аның Әвәләк сыртыннан*

*башланып, Кырык сыртны үтеп, ул татар урман-далаларына килеп чыга.* Ф.Бәйрәмова. *Ә Урта Иделдә һәм Уралдагы урман-далаларда күчмәлек була алганмы соң?* И.Хуҗин

**УРМА́Н КҮГӘРЧЕНЕ** *и. зоол.* Күгәрчен кошлар семьялыгыннан урманда яши торган кечерәк кенә кош; *русчасы:* **горлица**. *Нәкъ борылышта, Ык болыннарына карап үскән күп учарлы мәһабәт имәнгә җиткәч кенә исенә төште: имәннең иң куе ботаклары арасында табигать гүзәле – үтә сак һәм иркә кош – урман күгәрчене гөрли, аның тавышы бөтен якын-тирәгә серле моңсулык өсти торган иде.* Г.Бәширов. *Шул вакыт аның янына бер урман күгәрчене иязлы.* Г.Гыйльманов

**УРМА́Н-КЫР** *җый. и.* Урман, басу һәм кырлар. *Күз кырыннан чыгармавы яхшы: урман-кыр ач бүре белән тулы.* Ә.Моталлапов. Урман-кыр, басу-болын тулы киек-җәнлек, кош-корт булсын. Р.Батулла

**УРМАНЛЫ** *с.* Урман белән капланган, урманы күп булган. *Соң, үрле урман була алмый, урманлы үр була!* М.Хуҗин. *Мангыт-Нугай Урдасының күпсанлы халыкка ия булуы һәм зур хәрби куәте нәтиҗәсендә, XV–XVI гасырларда нугайлар далаларда гына түгел, Урта Идел буеның урманлы территориясендә дә мөһим роль уйнаганнар.* Б.Хәмидуллин

**УРМАНЛЫК** *и.* Урманлы җир, урман булган урын. *Әйләнә-тирәсен урманлык чолгап алган аэродром шәһәр янәшәсендә генә.* Ф.Хуҗин. *Безнең яклар урманлык, урман саен аланлык.* Ә.Гадел

**УРМА́Н САЕСКАНЫ** *и. зоол. к.* **күкшә**

**УРМА́Н СЫЕРЫ** *и.* Поши. *Яфрак астыннан, чыклы үләннәргә баса-баса, озын колаклы куян чыга; тармак-тармак мөгезле башын югары күтәреп, юеш борыны белән салкынча һаваны исни-исни, урман сыеры су эчәргә китә.* Г.Әпсәләмов. *Җиңелчә кулы калтыраган министр винтовкасын сузып, нарат кәүсәсенә терәде дә урман сыерын мушкага алды.* М.Галиев

**УРМА́Н ТАВЫГЫ** *и. зоол. к.* **суер**. *Кире урман юлына чыкканда, баш очларыннан, киң канатлары белән имән ябалдашларына тия язып, зур бер кош очып үтте. – Урман тавыклары һаман бармыни әле? – дип гаҗәпләнеп һәм сөенеп сорады Сәетҗан абый.* М.Маликова. *Кадерматовның аяк астыннан диярлек, чикләвек куаклары арасыннан, урман тавыгы пырхылдап чыкты да, куркуыннан нишләргә белмичә, сикерә-оча, агачлар арасына кереп югалды.* Г.Кашапов

**УРМА́Н-ТАУ** *җый. и.* Урманлы һәм таулы җирләр; гомумән урманнар һәм таулар. *Колхозларында эш бармый, бездә бит җирләр аз: кругом урман-тау.* Ф.Бәйрәмова. *Бу сурәткә карагач, чыннан да очасы килә: авылларны, урман-тауларны менә шулай югарылыктан күрәсе килә.* З.Мурсиев

**УРМАНТУ́НДРА** *и. геогр.* Төньяк ярымшарда урманнан (тайгадан) тундрага, тундрадан тайгага күчкән, урман белән тундра аралашкан табигать зонасы. *Урмантундра зонасы*

**УРМАНЧЫ** *и.* 1) Урман хуҗалыгында эшләүче кече хезмәткәр, урман каравылчысы, лесник. *Бернichә ел элек республика урманнарының хәвефсезлеген 4,5 мең урманчы саклаган.* Кызыл таң

2) Урман хуҗалыгының җитәкчесе, урманчылык (*2 мәгъ.*) мөдире, лесничий. *Карт урманчы белән бу соңгы очрашуыбыз булган икән.* Г.Гомәр. *Бер елны урманчы Хәбир бернichә чакрымлы, алты рәтле каен теземнәре утырттырды.* Р.Газиз

3) Урманчылык (*3–4 мәгъ.*) белән шөгыльләнүче кеше, урман белгече; *русчасы:* **лесовод**. *Урманчылар конференциясе*

**УРМАНЧЫЛЫК** *и.* 1) Урманчы булу; урманчы вазифасы, кәсебе, шөгыле. *Сугыштан соң бик озак госпитальдә дәваланып, тагын күпмедер вакыт урманчылыкка укып кайткач, егет гаиләдә өйләнү турында сүз кузгата.* Ә.Салах

2) Хуҗалык берәмлеге буларак урман участогы; шул участок белән идарә итүче оешма һәм шул оешма урнашкан хуҗалык корылмалары; лесничество. *Сайгаклык агач сөйләшергә дип, Айсинә күрше авылда гына урнашкан урманчылык хуҗалыгына китте.* Н.Көбәш. *Урманчылык белән аның хәзерге директоры Рәшит Таҗетдинов таныштырды.* Т.Нәҗмиев

3) Үсемлекчелекнең урман үстерү һәм аны саклау белән шөгыльләнә торган тармагы; *русчасы:* **лесоводство**. *Сентябрь башыннан Госман улымны урманчылык буенча укырга урнаштырырбыз, анда ашау да, кием дә бушлай диделәр.* Р.Хәбибуллина. *Әтигә әйтергә кирәк әле, урманчылык белгечләре белән киңәшсен.* М.Рәфыйков

4) Урман табигатен, урманнарны үстерү һәм яхшырту ысулларын өйрәнә торган фән; *русчасы:* **лесоводство**

**УРМА́Н ЧЫПЧЫГЫ** *и. зоол.* Чыпчык кошлар отрядыннан кечерәк кенә сайрар кош; *русчасы:* **завирушка**. *Мәсәлән, шәүлегән тавышы аның күңеленә шом бирә иде. Төнге ябалак тавышына да аның елыйсы килә – шулкадәр дә бәгырьне әрнетеп яңгырый бу тавыш. --- Ә менә урман чыпчыгының тавышына куана иде ул.* Г.Гыйльманов

**УРМА́Н ШӨЛДИЕ** *и. зоол. к.* **тәлләтәвеч**. *Караса, ни күрсен: аландагы сазлыкта урман шөлдие – вальдшнеп йөри.* Җ.Тәрҗеманов

**УРМА́Н-ЯЛАН** *и. к.* **урман-кыр**. *Гүя балтырган, кузгалак, кычыткан, чөгендер яфрагы кебек урман-ялан, бакча үләне белән түгел, ә бәлки гөбернатырлар, янараллар ашый торган затлы манпачилар белән тукланган солтанбикә!* А.Хәлим

**У́РНА** *и. лат.* 1) Кремацияләнгән мәетнең көлен саклый торган савыт; үлем символы буларак шундый савыт формасында эшләнгән кабер һәйкәле. *Менә без «1933–1945 еллардагы Гитлер диктатурасы корбаннарына» дигән сүзләр язылган таш стеналар буеннан, элеккеге концлагерьларның һәркайсыннан берәр уч туфрак китереп салынган зур гына таш урна яныннан үтәбез.* Р.Мостафин. *Бөтен уй-фикерне үзе миндә күмгән, Карынымны кабердәге урна иткән.* Н.Абдулкәримова

2) Яшерен сайлау вакытында бюллетеньнарны, шарларны сала торган тартма; шобага, лотерея һ.б.ш. уйнатылган вакытта билетлар, шарлар һ.б.ш. алына торган тартма. *Сайлауда, бюллетень алып, аларны урнага салмый чыгып киттем.* Р.Харис. *Тавыш бирү урналары, шул исәптән күчерелмәләре дә, үтәкүренмәле иде.* Кызыл таң

3) Җәмәгать урыннарындагы чүп савыты. *Башкалары урна тирәсендә чүпләнеп йөргәндә, бу [чыпчык] үзенә бер бәйрәм ясады.* Ә.Хәсәнов. *Алар [чит илдә] чүпне, пакетка төреп, өйләренә алып кайталар да матур итеп урнага салалар.* Х.Ибраһим

**УРНАШ** *и. диал.* 1) Яшьләр үзара акча салышып яки ашамлыклар алып килеп үткәрелгән аулак өй; шулай җыелган акчалар һәм ашамлыклар. *Аулак өйләр һәм урнаш кичәләре элекке елларда*

*мәгълүм бер басынкылык һәм кысынкылык астында үттеләр.* Г.Гобәйди

2) Келәү, келәү өчен пешерелгән ритуаль ризык. *Тавык суеп, урнаш пешерсә, булмый кала диме?* А.Хәлим

**УРНАШТЫРУ** *ф.* 1) Берәр нәрсәне кая да булса кую, урын табу. *Пугачёв шәхсән үзе, җир астына төшеп, дары мичкәсе һәм шәм урнаштыра.* В.Имамов. *Солтангали абзый учак тергезергә кала, алып килгән әйберләрне урнаштыра, утырыр өчен уңайлы урын сайлый.* Г.Госман

2) Нәрсәләрне дә булса билгеле бер тәртиптә тезеп кую. *Китапларны урнаштырып бетергәч кенә, теге кенәгәне кабат кулга алдым.* М.Кәбиров // Берәр нәрсәне тиешле, кирәкле рәвештә төзү, ялгау, монтажлау, системага кертү. *Үзебезнең проект белән азык цехы төзеп куйдык, төрле җиһазларны урнаштырдык.* Т.Нәҗмиев

3) Бинага, берәр урынга кемне дә булса яки нәрсәне дә булса кертеп кую, шуның карамагына бирү, тапшыру. *Гөлшәһидә аны [Сәхипҗамал җиңгине] үз хастаханәләренә урнаштырды.* Г.Әпсәләмов. *Чемпионатта катнашу өчен киләчәк командаларны урнаштыру белән дә өзеклек булырга тиеш түгел.* Кызыл таң

4) Яшәү урыны табу, торак белән тәэмин итү

5) Кемне дә булса берәр урынга (эшкә, укуга һ.б.) кертү, билгеләү. *Ләйсәннең әтисе дә, вакытны озакка сузмый, кызын түләүле әзерлек курсларына урнаштырды.* А.Хәйретдинова. *Әнисе Мәскәүдә театр институтында (ГИТИС) уку сәбәпле, аны Мәскәүдәге бер балалар йортына урнаштыра, Равил җиде сыйныфны шунда тәмамлый.* Г.Мөхәмммәтшин

6) *сөйл.* Кызны, хатынны кияүгә бирү // Уңышлы итеп кияүгә бирү. *Алар [Нәсимәләр] кече кызларын Тутаев улына биргәннәр икән. Кешеләр кызларын урнаштыра белә.* А.Гыйләҗев

7) Язманы, текстны җыентыкка, китапка, журналга һ.б. кертү. *Шуннан соң наширләрнең принцибы кинәт үзгәргән: экономия йөзеннәнме, алар гарәпчә һәм татарча текстларны бер үк биткә урнаштыра башлаганнар.* А.Тимергалин. *Университетның ректоры газета битләренә зур-зур интервьюлар урнаштырды.* Ф.Яхин

8) Нинди дә булса бер хәлне, торышны булдыру, барлыкка китерү. *Кыпчак далаларында туып, саф дала һавасын сулап үскән кыз, Сәлим ханга килүгә, үз тәртипләрен урнаштырды.* М.Хәбибуллин. *[Сакманов] Украина, Прибалтика эшкуарлары белән элемтәләр урнаштырды.* Т.Галиуллин

9) Нинди дә булса сәяси тәртипне законлаштыру, гамәлгә кертү һәм ныгыту. *Менә яңадан совет власте урнаштырсак, җимерүе җиңелрәк булачак инде анысы.* Җ.Юныс. *Кызганыч ки, тарихи барыш башка юлдан китә: большевиклар сүздә Россия империясендә яшәүче милләтләргә «үзбилгеләнү» хокукы вәгъдә итсәләр дә, гамәлдә илдә тоталитар режим урнаштыралар.* М.Хәсәнов

10) *информ.* Компьютерның хәтеренә кертү. *Яңа программа урнаштыру*

11) *күч.* Тарату, сеңдерү, тотрыклылыгын тәэмин итү. *Халык арасында ныклы фикер урнаштыру*

**Урнаштыра бару** Рәттән һәрберсен урнаштыру. *Штурман Артур, алар китергән әйберләрне кабул итеп, рубкага менә торган баскыч астындагы зур ларга тутыра, кубрикка төшереп урнаштыра бара иде.* С.Сабиров

**Урнаштыра башлау** Урнаштырырга тотыну. *Гаффан, осталарны җыеп, урам яклап алынган койманы үз урынына урнаштыра башлады.* Г.Гыйльманов

**Урнаштыра тору** Нәрсәдер башланганчы яки җиткәнче, шуның алдыннан урнаштыру. *Ә мин монда тәртип урнаштыра торам.* М.Кәбиров

**Урнаштырып бару** *к.* **урнаштыра бару**. *Шулай ук әдәби портретларны да системалы рәвештә һәр сан саен урнаштырып барырга кирәк.* З.Нури

**Урнаштырып бетерү** Барысын да урнаштыру, урнаштыруны төгәлләү. *Ничек яшисең – шулай яшә, калганын Ходай Тәгалә үзе җайлап урынына урнаштырып бетерә ул.* Г.Гыйльманов

**Урнаштырып йөрү** Озак вакыт урнаштыру. *Син ничәмә-ничә ел буена фронтларда сугышып, ничәмә-ничә кала-бистәләрдә Совет власте урнаштырып йөрдең.* В.Имамов

**Урнаштырып кую** Тиз арада яки алдан урнаштыру. *Янына килеп, скафандрындагы ниндидер төймәләргә баскалаган иде, Саимә белән телепатик элемтә дә урнаштырып куйды.* Ф.Имамов

**Урнаштырып тору** Даими урнаштыру; әле, хәзер урнаштыру, вакытлыча урнаштыру. *Төнге патрульдән кайтуга, кардәшләре белән киңәшкәч, Балҗанны үзләрендә урнаштырып торырга тәкъдим итте.* Т.Әйди

**Урнаштырып чыгу** Тулысынча, берсен дә калдырмыйча урнаштыру. *Шулар өстенә, Казанда, шәһәр буйлап, Тукайлы 50 баннер урнаштырып чыкканнар.* Шәһри Казан

**УРНАШТЫРЫЛУ** *ф. төш. юн. к.* **урнаштыру**. *Һәм, ниһаять, октябрь аеның азаккы көннәрендә Казанда Совет власте урнаштырылды...* М.Хәсәнов

**Урнаштырыла башлау** Урнаштырылырга тотыну. *Чит илләр белән турыдан-туры элемтәләр урнаштырыла башлады.* Р.Миңнуллин

**Урнаштырылып бетү** Барысы да, булган берсе урнаштырылу. – *Сездә дә әле өй җиһазлары урнаштырылып бетмәгән икән, – диде Нур, бүлмәләрне карап чыккач.* Р.Гариф

**УРНАШУ** *ф.* 1) Билгеле бер урында булу, нинди дә булса урынны биләү, алып тору (предмет, бина һ.б.ш. тур.). *Механический цех белән тимерчелек цехы бер корпуста урнашкан.* А.Алиш. *Кояш системасында Җирдән арырак урнашкан күрше планета Марс дип атала.* А.Тимергалин

2) Берәр җирдә билгеле бер вакытка тукталып урын алу. *Төн уртасында, шуышып кереп, авыл кырыендагы бер ташландык мунчаның өчырмасына урнаштык.* М.Мәһдиев. *Команданы яр буенда зур гына үзйөрешле баржа көтеп тора иде. Кереп урнаштылар.* Р.Кәрами // Урын алып, җайлап утыру, яту. *Өчәүләп табын тирәсенә урнаштык.* Г.Тавлин. *Безгә дигән палаткалар инде корылган. Бишәр-алтышар урнаштык.* З.Мәхмүди

3) Гомер итү, яшәү өчен билгеле бер урынга төпләнү. *Без шәһәрдә урнаштык. Андагы яшәү яшәү түгел иде инде әни өчен.* Н.Гыйматдинова. *2000 елда аның [Сәгыйть хәзрәтнең] оныкчыклары Үзбәкстаннан Чепьяга кайтып урнаштылар.* Р.Зарипов

4) Эшкә керү, нинди дә булса хезмәт урыны, вазифа алу. *Олы улым, ФЗУны бетереп, яхшы гына урынга урнашты, жалуниясе дә яхшы.* Г.Камал. *Берәүләр эшкә урнашты, кайберәүләр профтехучилищеларга керде...* А.Гыйләҗев

5) Башлы-күзле булып, тормышта үз урынын табу. *Ике балам да күптән урнашты, аерым яшиләр.* Р.Мирхәйдәров

6) Башлану, хөкем сөрә башлау, утыру (табигать күренешләре, климат тур.). *Җуйды урман гүзәл яшеллеген, Көз урнашты анда яңадан. Балкый кояш, әмма аның җәйге Җылылыгы инде калмаган.* Р.Зарипов. *Эңгер-меңгер төште, хуҗа килер алдыннан аллеяларга шлангтан су сиптерделәр, бакчада яңгырдан соң була торган салкынча-саф һава урнашты.* Р.Мирхәйдәров

7) Нинди дә булса мөнәсәбәт, караш һ.б.ш. туу, барлыкка килү. *Нәтиҗәдә эчкерсез дуслык урнаша.* Г.Гомәр. *Ике арада тагын киеренке салкынлык урнашты, күзгә күренми торган киеренке көрәш башланды.* В.Имамов // Нинди дә булса хәл, тәртип, торыш туу, хөкем сөрә башлау. *Шәмгыя әби килеп, «Ясин» сүрәсен укый башлауга, өйдә тагын да авыр тынлык урнашты.* А.Хәйртдинова. *Әйе, Ишук-Ишмөхәммәт бик яхшы белә: яңа патша килгән саен яңа тәртипләр урнаша* ---. Ф.Бәйрәмова

8) Берәр нәрсә ныгу, гадәт булып китү, традициягә керү. *Русия матбугаты аша, янәсе, базарга күчү авторитар режимны, гадәттән тыш чараларны һәм көчле хакимиятне таләп итә, дигән дөрес булмаган фикер урнашты.* Р.Хәкимов // Тиешле, гадәти торышын, хәлен алу. *Мәктәп тормышы үз агышына урнашты кебек.* Р.Батулла

9) Нәрсә дә булса рәсми төс алу, формалашып бетү, ныгу. *Ил яктырды, җәбер-золым бетте, Рәхәт тормыш килеп урнашты!* М.Җәлил. *Совет власте китмәслек, җимерелмәслек булып мәңгелеккә урнашты.* В.Имамов

10) *куч.* Күңелдә, йөрәктә урын алу, биләү, тирән эз калдыру. *Петронның яраланган йөрәгенә нindидер якты бер тойгы кереп урнашты.* Г.Әпсәләмов. *Күңелемнең бер почмагына авыр тойгы кереп урнашты.* З.Хөснияр

**Урнаша бару** Торган саен ныграк урнашу; бер-бер артлы урнашу. *Оныклар, үсеп, бер-бер артлы калага китеп урнаша барды, шунда гаилә корды.* Г.Әдһәмова

**Урнаша башлау** Урнашырга тотыну. *Асия белән Гөлшәһидә арасында дуслык урнаша башлады.* Г.Әпсәләмов

**Урнаша тору** Нәрсәдер башланганчы, нәрсәдер җиткәнче урнашу; һаман бер-бер артлы урнашу. *Балалары үсә тора, Салават шәһәрендә яшәүче олы кызы Рәзимә янына барып эшкә урнаша тора.* Кызыл таң

**Урнашып алу** Тиз арада урнашу; тулысынча урнашу. *Ниһаять, көннәр тәмам җылынып беткәч, чит яклардан соңлабрак кайткан бер пар сыерчык урнашып алды бу купшы ояга.* Г.Гыйльманов

**Урнашып бетү** Тәмам урнашу. *Сугыш, куптарып, төрле якларга сибеп ташлаган кешеләр әле урнашып бетмәгәннәр, ахры.* А.Гыйләҗев

**Урнашып җитү** Тиешле дәрәҗәдә урнашу. *Күргәнебезчә, төп әдәбият белән әлеге «суверен держава» арасында тирән дипломатик мөнәсәбәтләр урнашып җитмәгән әле бездә.* Р.Миңнуллин

**Урнашып йөрү** Билгеле вакыт дәвамында урнашу. *Зәкия эшкә урнашып йөри түгелме соң?* Г.Галиева

**Урнашып калу** Урнашырга өлгерү; кисәк урнашу. *Әйләнә-тирәдә шомлы тынлык урнашып калды шул мәлдә.* Р.Мөхәммәдиев

**Урнашып карау** Белү, сынау максаты белән урнашу. *Аннан лаборантка булып эшләп алдым, тегендә-монда урнашып карадым.* Шәһри Казан

**Урнашып килү** Урнаша башлау; соңгы арада урнашу. *Инде фотосурәт, видеосурәт, фильмнар төшереп, тантаналы, истәлекле гаилә вакыйгаларын теркәп калдыру гадәтләре урнашып килә.* Ш.Галиев

**Урнашып китү** Билгеле бер моменттан соң урнашу. *Алга таба «Ганка» иселе татар әдәби телендә ахмаклык, аңгыралык символы буларак урнашып китә.* Х.Мәхмүтов

**Урнашып кую** Алдан яки тиз арада урнашу. *Сезгә мөрәҗәгать иткән кеше тиз һәм ансат кына эшкә урнашып куймый алайса.* Шәһри Казан

**Урнашып тору** Хәзер, әле урнашу; вакытлыча урнашу. *Ачылышыннан алып 1950 нче еллар азагына кадәр ул хәзерге «Нурулла» мәчетендә урнашып тора.* Безнең мирас. *Моңа кадәргесеннән кайтышрак булса да, эш табып урнашып тора.* Ватаным Татарстан

**УРО́ЛОГ** *и. гр.* Урология белгече. *Җитмәсә тагын, шунда невропатолог белән уролог бертавыштан: «Хатын-кыз табарга кирәк сиңа», – дип киңәш иттеләр.* Ә.Сафиуллин

**УРОЛО́ГИК** *с.* Урология белән бәйле, шуңа караган. *Бүгенге көндә урологик чирләрнең бигрәк тә ирләр арасында таралуы кискен проблемалар тудыра.* Кызыл таң

**УРОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Медицинаның җенес-сидек органнары авыруларының килеп чыгышын, диагностикасын һәм аларны дәвалау, булдырмау юлларын өйрәнә торган тармагы. *Садыйков авырый, бөтен урология бүлеге, бөтен кафедра аның кулында...* Г.Әпсәләмов. *Галимнең икенче улы Искәндәр – Мәскәү шәһәрендә урология хирургы.* Г.Мөхәммәтшин

**УРПАН** *и. фар. иск.* Зурлык, авырлык, ара кебекләрне махсус приборларсыз гына билгели белү осталыгы, күз күреме белән чамалау сәләте // Шундый сәләткә ия кеше // Ат маклеры. *Татар ат маклерлары, урпаннар бөтен Рәсәйдә танылган булган.* Р.Әхмәтьянов

**УРПАНЛА́У** *ф. иск.* Күз күреме белән үлчәү; күз белән чамалау

**УРСА́Й** *и. к.* **урсәни**. *Кәбен койдыру үзенчәлекләре, йөклелек чорында хатын-кызның ураза тоту шартлары, урсәти, урсай (әнитүти) сайлап, баланы чумылдыру, исем кушу темаларына аеруча зур игътибар бирелде.* Туганайлар

**УРСАТАЙ** *и. к.* **урсәти**. *Җәкәү дәдәй – безнең әбинең энесе, әтинең урсатасы, ә без аны «урсәти бабай» дип йөртә идек.* Туганайлар

**УРСӘНИ** *и.* Христианнарда чукындыру йоласын үткәргәндә чукындырыла торган баланың рухи тәрбиясе өчен Ходай каршында өстенә җаваплылык алган һәм киләчәктә баланың рухи анасы саналган хатын-кыз; *русчасы:* **крёстная мать**. *Балаларны чумылдырганда урсәти дә, урсәни дә булуы мәҗбүри түгел, малайлар өчен урсәти, кызлар өчен урсәни булуы да җитә.* Туганайлар

**УРСӘТИ** *и.* Христианнарда чукындыру йоласын үткәргәндә чукындырыла торган баланың рухи тәрбиясе өчен Ходай каршында өстенә җаваплылык алган һәм киләчәктә баланың рухи атасы саналган ир кеше; *русчасы:* **крёстный отец**. *Хәзерге вакытта яшь балаларны чумылдырганда, урсәти белән урсәни булырга тиеш, ә олы кешеләр чумылганда, алар мәҗбүри түгел.* Туганайлар

**УРТ** *и.* 1) Яңакның эчке ягы. *Уртка ак төшү. Ялгыш уртны тешләү*

2) Теш тамырларын каплый торган мускуллы тукыма; теш ите. *Тешсез урт кебек нигез урыннары убылып калган авыл уртасында галәмәт зур, биек бер йорт кукыраеп тора иде шул.* М.Вәлиев. *Мирзаян ашап бетермәгән пәрәмәчен шинель кесәсенә тыкты да, пычрак*

*бармагы белән уртын казый-казый, түбән очка таба йөгерде.* Ә.Дусайлы

◊ **Урт итен ашау** *к.* **урт итен чәйнәү**. **Урт итен чәйнәү** Ярсуын, тирән ачуын көчкә тыю, тыелып калу. *Боларның барысын да күзәтеп торган Сүбәдәй, беренче һөҗүмнең сүтелүен күреп, урт итен чәйнәде, бармак буыннары агарганчы камчы сабын кысты.* М.Хәбибуллин. **Уртын чәйнәү** *к.* **урт итен чәйнәү**. *Тимучин гына Бөртекбикә тирмәсенә атналар буена кереп карамады, кара көеп һәм урт чәйнәп йөрде.* В.Имамов

**УРТА** *и.* **1.** 1) Нәрсәнең дә булса кырыйларыннан, очларыннан азмы-күпме тигез ераклыктагы урын; нәрсәнең дә булса үзәге. *Мәйдан уртасында, Миләүшә елгасы янында халык уеннары башланды.* А.Алиш. *Үзәннең нәкъ уртасында түп-түгәрәк күл ялтырап ята икән.* А.Имамиева

2) Нинди дә булса вакытның башы белән ахыры арасындагы өлеше. *Май ае урталарында дембельләрне өйләренә озата башладылар.* З.Мәхмүди. *Көн уртасында авыл җирлегенә олы яшьләрдәге бер хатын килеп керде.* А.Нәҗми

3) Нинди дә булса вакыйга үсешендә, дәвамында башы белән ахыры арасындагы вакыт. *Ләкин миңа эш башында рух биргән идарә мөхәррирләре эш уртасында мине мәсхәрә иттермәделәр.* Г.Тукай. *Мәҗлеснең нәкъ уртасында, нәкъ кирәк сәгатендә, юбилярның нечкәргән күңелен тагын да нечкәртеп, «Дулкын»нан, өй хуҗасы Хәйруллин Галимулла исеменә атап, татар халык җыры яңгырый.* Б.Рәхимова

4) Нәрсәнең дә булса игътибар үзәге. *Шәһәр башлыгы мәҗлеснең уртасында булырга тиеш иде, Козецкий, үчегеп, аны чакырмады.* А.Гыйләҗев. *Шулай итеп, көн тәртибендәге беренче мәсьәләне уртага куеп сөйләшүне һәм фикерләр йөртүне төгәлләргә кирәк дип саныйм.* А.Хәмзин

5) Укучыларның белемен бәяли торган уңай билгеләрнең иң түбәне; өчле. *Роберт һәм аның белән бер тирәдәгеләрне хутордан мөгаллимә апа килеп укырга-язарга, хисап башлангычларына өйрәтә, хәтта журналга «яхшы», «урта», «начар» билгеләре дә куя торган була.* А.Тимергалин

6) Өлгереш, күрсәткечләр ягыннан бик артта да калмаган, бик алга да чыкмаган хуҗалык, оешма һ.б.ш. *Шул ферма хәзер урталар рәтенә күтәрелгән, хәтта яхшы исәптә йөртәләр үзен.* Ф.Хатипов. *Кабат әйтәм: урталарга таян. Алар райком сүзеннән чыкмый, урталар күп, планны алар үти, районны алар алып чыга...* Г.Ахунов

7) XX гасыр башында Россиядә зур булмаган җир кишәрлеге булган, шуны үзе яки гаилә әгъзалары белән эшкәртүче аерым хуҗалыклы крестьян, урта хәлле крестьян (милек хәленә карап ярлылар белән кулаклар арасында булган). *Алпавыт, кулакларны сөрделәр. Урталар калды.* Р.Батулла

**2.** *с. мәгъ.* 1) Кырыйлардан бертигез ераклыктагы ике нокта, сызык, предмет арасына урнашкан. *Урта күчәрнең подшипнигы ук таралганын күргәч, Рәшит аптырашта калды.* В.Нуриев. *Инде чыдарлыгы калмаганда, өметләре өзелгәндә, Сабит кайтып керде, урта бармагын изәп, Нәҗипне кабинетка чакырды.* А.Гыйләҗев. *Ике катлы таш йортның аскы катында урта тәрәзәдә сүрән генә ут күренә.* А.Әхмәтгалиева. *Самолётта очканда, урта колак һәм әйләнә-тирә мохит арасында басым бозылганлыктан, колакта сызлау барлыкка килә.* И.Касыймова

2) Вакыт аралыгының, чорның һ.б.ш.ның башы белән ахыры арасындагы; үсеш этапларының арадашына караган. *Урта гасырлар әдәбияты чынбарлыкны бик үзенчәлекле чагылдыра.* А.Әхмәдуллин

3) Үзенең сыйфаты, үзлеге ягыннан ике билге яки зурлык арасындагы, арадаш. *Анда бик салкын вә бик эссе түгел, урта һава.* Г.Тукай. *Урта яшьләрдәге бер ир-ат, зур ташлы алтын балдак кигән кулын чыгарып, тәмәкесенең көлен җиргә какты.* А.Мансуров. *Мең тугыз йөз кырык бишенче елның язында Исхак урта мәктәпне тәмамлады.* А.Гыйләҗев. *Өченче көнне, яшьләр һәм урта буын кешеләре өчен, иртәдән төшкә кадәр бәйрәм булачак.* А.Нәҗми

4) Яхшы да, начар да түгел, бер ягы белән дә аерылып тормаган, гади; артык көчле булмаган; уртача. *Урта эшче. Урта белгеч*

5) Унбер ел укытуга нигезләнгән. *Әмма дүрт аяклы малны никадәр генә сөйсәм дә, урта белемле башым белән ат караучы, ягъни кунних булып калу авыл егетләре --- алдында минем авторитетны нык кына какшата башлады.* А.Хәсәнов

◊ **Урта бармак кебек (шикелле)** Барлык яктан да килгән, бик яхшы. *– Шәмсетдин акыллым, – диде Нәфисә миңа шунда, – авылыбызда син беренче матур егет, аннары егетнең дә менә дигәне: урта бармак шикеллесе, акыллысы, аңлысы...* А.Шамов. **Уртага куеп** *к.* **уртага салып**. *Бу нидән килә? Уртага куелган мәсьәләнең шул халыкның тормышыннан, иҗтимагый тарихыннан суырып алынмавыннан килә!* Г.Ибраһимов. **Уртага салып** Киңәшләшү, тикшерү йөзеннән, нинди дә булса мәсьәләне ачыктан-ачык белдереп, яшермичә. *Бөтенесен уртага салып киңәштеләр дә шунда ук бер сүзгә килделәр.* Г.Бәширов. **Урта кул** Уртача, бик үк сыйфатлы яки бик зур да, бик кечкенә дә булмаган; бик алдынгы да, бик артта калган да түгел. *Алда калкан, артта калкан, ә ике уртада син, ягъни урта кул җитәкче, балык кебек йөзәсең.* Г.Әпсәләмов. *Аларның урта кул авылы үзенә аерым күмәк хуҗалык түгел, ә зур «Дуслык» хуҗалыгының бер бригадасы иде.* Р.Фәизов. *Чөнки түбән дәрәҗәдә язылган операны урта кул режиссёрдан куйдыртып, урта кул тавышлы җырчыдан җырлату сәнгатебезне күтәрү булмас иде.* Р.Миңнуллин. **Урта хәлле** Көнкүреше уртача булган, бай да, ярлы да түгел, гадәти тормышлы. *– Сезнең авылдагы көнкүрешегез ничек иде? – Урта хәлле крәстиән.* А.Алиш. *Ярлыларда, урта хәллеләрдә һәм байларда иртәнге аш, көндезге аш һәм кичке аш нәрсәләрдән тора?* Г.Рәхим

**УРТАГЫННАН** *рәв. к.* **уртакка**. *Кыр печәнен кемгә булса да уртагыннан биреп эшләтергә булды.* Н.Яһудин. *Фарукҗан бу көннәрдә, мамыкның, киптерелгән җимешләрнең чын бәясен иптәшләреннән сорашып, җирен уртагыннан файдаландырган байның авылдашларын күпмегә алдавын анykларга омтылды.* Т.Әйди

**УРТАК** *с.* **1.** 1) Барлык кешеләргә, барлык нәрсәләргә бердәй карый торган; барлык кешеләрне, барлык нәрсәләрне эченә алган; гомуми. *Безнең бабаларыбыз, әтиләребез уртак Ватаныбызны бергәләп сакладылар.* А.Хәмзин. *Халыкларның уртак төрмәсендә Шагыйрьләр дә торкын, зынҗырлы.* Г.Морат

2) Кем белән дә булса бергә эшләнгән, башкарылган, үтәлгән. *Әнә коридорның теге ягында – канцеляриядә – эчке-тышкы идарәнең уртак җыелышы бара.* Г.Ибраһимов. *Хәзер кешеләр уртак эш өчен үз кәефләрен корбан итә алмыйлар.* А.Гыйләҗев

3) Берничә яки барлык кешегә карый торган; иясе бер генә булмаган. *Бәлки, берәр төрле могҗизадыр бу: бик яраткан, сагынышкан кешеләрнең уртак балалары буладыр?* Г.Гыйльманов

4) Кем белән дә булса охшаш, бертөрле; икенче берәүгә яки икенче нәрсәгә дә хас. *Алдашу, урлашу, мораль таркалганлык – боларның барысы өчен дә уртак сыйфат.* Г.Камал. *Шунысы да әһәмиятле: фәнни продукт тудыру процессы белән сәнгать продукты тудыру процессы арасында уртак моментлар да юк түгел.* К.Гыйззәтов

5) *мат.* Бирелгән берничә санга калдыксыз бүленә торган яки бирелгән саннарны калдыксыз бүлә торган. *Уртак бүленүче. Уртак бүлүче*

**2.** *рәв. мәгъ.* Тигез итеп, яртылаш, урталай. *Рәнҗешнең барыбызга да уртак төшү мөмкинлеген дә онытма...* Г.Галиева. *Халыкларның уй-хисләрен, җырын, язмышларын Чаллы уртак бүлә.* К.Сибгатуллин

**3.** *и. мәгъ.* 1) Бергәләп эш иткән, нәрсәгәдер бергәләп ия булган кешеләрнең һәрберсе; шәрик, пайчы. *Үгезе үлгән, уртагыннан аерылган.* Әйтем

2) Пай, өлеш. *Картның, бу җәмәгать уртагыннан башка, тик үзенә караган бер печәнлеге бар.* Г.Ибраһимов

**4.** *хәб. мәгъ.* 1) Бөтен кешенеке дә, һәркемнеке. *Бары – бергә, югы – уртак.* Әйтем

2) Бер-берсенә охшаш, бертөрле. *Милли татар көрәше һәм билбау көрәше – берсенә берсе тиңдәш көрәшләр, көрәш алымнары да күбесе уртак.* Г.Шәйхи

3) Ниндидер эшне бергәләп башкаручыларның, кичерешне бергәләп уздыручыларның берсе булу турында. *Курка башны кузгатырга Кәҗәкуркак, Күптән инде куркаклыкка Сарык уртак.* Г.Тукай

◊ **Уртакка алу** Уртаклашу, бергәләп кичерү. *Күзәтүчәнлеге, хәтер байлыгы, кешеләр хәсрәтен кичкенәдән үк уртакка алып үсүе аңа язучы булырга һичшиксез булышкан.* М.Хуҗин. **Уртак тел** Кем белән дә булса аңлашу; сөйләшер сүз, уртаклашыр фикер. *Нигъмәт казый бөтенләй ачу белән кабарынды, сезнең белән уртак телем юк минем, дип, чыгып китәргә атлады.* Г.Ибраһимов. **Уртак тел табу** 1) Килешү, аңлашып, уртак фикергә килү, бер-берең белән аңлашу хәленә җитү. *Ахыргы вакытта уртак тел таба алмый башладылар яшьләр.* А.Мансуров. *Синең белән уртак тел табып була.* Д.Салихов; 2) Нәрсәнең дә булса җаен табу, өйрәнү. *Гармун белән уртак тел тапкан егет кызлар йөрәгенә иң кыска юлны тапмас, ди!* Д.Гыйсметдин. **Уртак фикергә килү** Берничә кеше, киңәшеп, бер нәтиҗә чыгару, килешү. *Уйлашканнар, киңәш-табыш иткәннәр, ләкин уртак фикергә килә алмаганнар.* З.Хөснияр. *Барысы да, чишмә буена төшәргә, дигән уртак фикергә килделәр.* И.Нәбиуллина

**УРТАККА** *рәв.* 1) Берәр нәрсәне кем белән дә булса бүлеп, бергәләп. *Без Лотфулла белән уртакка ике зур әсәр эшләдек.* Р.Вәлиев. *Мунчаны алар күптәннән – сугыш чыкканнан бирле – күрше-күлән белән бергәләшеп, уртакка ягалар.* Р.Мулланурова

2) Ярты уңышны, ярты табышны җир хуҗасына, мал иясенә бирү шарты белән. *Биктимер: Әйе, улым, җиде җанга бер имана булгач, безнең тормыш шул инде – уртакка чәчеп, кеше туйдырып ятабыз.* Т.Гыйззәт. *Соңгы елларда Һашимовка хуҗалыгын киметергә туры килде: ул артык хайваннарның кайсын кая сатты, кайсын уртакка асрарга бирде.* А.Алиш

**УРТАКЛА́У** *ф.* 1) Нәрсәне дә булса урталай бүлү. *Алар аны урманчы белән уртаклап эшләделәр.* А.Шамов

2) *к.* **уртаклашу** (*3 мәгъ.*). *Каш җыермый, һәрвакыт шат, ул шулай татлы көлә, Әнкәсенең кайгы-хәсрәтен гел уртаклый белә.* Г.Харис

3) Берләштерү, күпләр өчен уртак итү. *Менә кайчан кирәк ул тиңдәшсез олы сүзләр! Җаннарны уртаклый торган, Әүлияларны һәм мине бергә Күккә күтәрә торган догаларны мин белмим.* А.Гыйләҗев

**Уртаклый башлау** Уртакларга тотыну. *Күп нәрсәләрне уртаклый башладыгыз сез, иптәш Мөслимова.* Д.Зөбәерова

**УРТАКЛАШУ** *ф.* 1) Нәрсәне дә булса үзара бүлешү. *Ул [приказчик] бөтен табышын аның белән бүлешә башлады; әйтик, ул таныш бер кешесенә йөз сумлык товар сатып җибәрә икән, кассага шуның ун сумын гына сала, ә калган акчаны дусты белән уртаклаша иде.* М.Галәү. *Янбаш – сарыкның иң итле җире, андагы итне ашап бетереп булмый, анысын да уртаклашырга туры килде.* Р.Батулла

2) *күч.* Белгәнеңне башкаларга да сөйләү, аңлату. *Чит илгә барырга? Тәҗрибә уртаклашып кайтуың ярый анысы.* Н.Хәсәнов. *Родос утравының кайдалыгын чамалый башлауга ук, чәчәк түтәлендәге туфрак өстенә таяк белән сызгалый-сызгалый, белемен уртаклаша.* В.Имамов

3) *күч.* Белгәнеңне башкаларга ачу, башкалар белән бүлешү. *Вадим Зуфирәдән тиз генә җавап көтми, аның бары тик эчендәге зарын кемгәдер сөйлисе, серен уртаклашасы килә иде булса кирәк.* М.Маликова

**Уртаклаша бару** Булган берсе белән уртаклашу. *Үзенең ни бар кайгыларын, совет, революция эшләрендәге барлык уңышларын һәм аяк таюларын, иң зур мәсьәләләрдәге фикерләрне һәр көн ашаган-эчкәндә, кич йоклау алдында аның белән уртаклаша барды.* Г.Ибраһимов

**Уртаклаша башлау** Уртаклашырга тотыну. *Авыл кешесенең шул инде: шатлыгын уртаклаша башласа да, авызы кара кан белән тула.* А.Гыйләҗев

**Уртаклашып алу** Аз гына уртаклашу. *Абзый, яңадан аракы койганда, сүз ара сүз өчен генә, үз белеме белән уртаклашып алырга булды, күрәсең.* А.Хәлим

**Уртаклашып җиткерү** Тулысынча уртаклашу. *Ул [Давыт], мәсәлән, революционер булу – хатын-кыздан бөтенләй баш тарту, дигән карашны тулысынча бервакытта да уртаклашып җиткерми.* М.Хәсәнов

**Уртаклашып йөрү** Билгеле вакыт дәвамында уртаклашу. *[Йосыф Акчура] Германиягә китә, әсирлектәге мөселман тоткыннарының моң-зарларын уртаклашып йөри.* М.Гайнетдин

**Уртаклашып карау** Белү, сынау максаты белән уртаклашу. *[Килмешәк] түзми, кичәге тойгылары белән уртаклашып карарга була.* К.Җәмит

**Уртаклашып килү** Күптәннән, эзлекле рәвештә хәзергәчә уртаклашу. *Шатлыклы хәбәрләре белән Коля саранланмыйча уртаклашып килә.* Ә.Мушинский

**Уртаклашып китү** Билгеле бер моменттан башлап уртаклашу; уртаклашып үтү. *Мин тик үз күзәтүләрем нәтиҗәсендә туган фикерләрем белән уртаклашып китүне кирәк дип таптым.* В.Нуруллин

**Уртаклашып тору** Һәрвакыт, даимән уртаклашу; хәзер, әле уртаклашу. *Менә 20 ел чамасы инде ул [Тәүфикъ Әйди] дөнья гизеп йөргәндә күр-*

*гәннәрен матбугатта әледән-әле безнең белән уртаклашып тора.* З.Рәмиев

**Уртаклашып үтү** Эш уңаенда уртаклашу. *Тик кайбер күзәтүләр белән «юл уңаеннан гына» уртаклашып үтик.* Ф.Урманче

**УРТАКЛЫК** *и.* **1.** 1) Күпләр өчен уртак булу, гомумилек, күпләргә карау. *Әмма кешеләрне үзара якынайтуда тел уртаклыгының роле артыграк.* Р.Мөхәммәдиев

2) Бердәйлек, охшашлык, туры килгәнлек. *Бәхетсезләргә монда күңелләр ачык, язмыш уртаклыгы аларны берләштерә.* А.Гыйләҗев. *Өч заманның уртаклыгын тапкан Адәм тиңсез эшләр кыла ала!* И.Юзеев

**2.** *с. мәгъ. лингв.* Бер төрдән булган предметларның, затларның барысы өчен дә уртак булган (исем сүз төркеме тур.). *Уртаклык исем*

**УРТАКЛЫ́К ЮНӘЛЕШЕ** *и. лингв.* Бер үк эшнең яки хәлнең ике яки берничә субъект катнашы белән үтәлүен белдергән фигыльнең грамматик категориясе

**УРТАКТАН** *рәв. к.* **уртакка**. *Исәбе – ничек тә серне яшерергә, байлыкны уртактан бүлешмичә, үзенә генә учларга иде аның.* Ф.Яхин

**УРТАКЧЫ** *и. тар.* Уртакка (*2 мәгъ.*) эшләүче. *Әйтик, тарихи чыганак буларак гаять кызыклы һәм дә бай ярлыкта – Тимеркотлык ярлыгында – Җучи олысындагы ике төрле игенче телгә алына: аларның берсе – сабанчы, икенчесе – уртакчы (уртактан, бергәләп эшләүчене аңлата).* Р.Фәхретдинов

**УРТАЛАЙ** *рәв.* Чагыштырмача тигез итеп ике кисәккә, уртадан. *Күкне кап урталай ярган аксыл пута менә шул тамчылардан тора, имеш.* А.Тимергалин. *Әмирнең йөрәге-җаны, нәкъ сабан белән ерып чыккан шикелле, кыл урталай ярылгандай булды.* В.Имамов

**УРТАЛЫК** *и.* 1) Билгеле мәйданның, аралыкның чигеннән, кырыннан чагыштырмача тигез ераклыктагы урын, урта бер төш, нәрсәнеңдер уртасы; үзәк җир. *Бакчаның барлык җиһазларын карап бетергәч, Тойгы туташ урталыктагы зур күл янына килеп чыккан.* Н.Думави. *Урталыкта үскән карт каенның Куышында булды «почтабыз».* Ф.Дәүләтгәрәева

2) Билгеле процессның башыннан ахырына кадәр узган вакытның чама белән урта моменты. *Беренчеләрдән булып керсәң, сорауны күп бирәләр, артка калсаң, надан булып күренәсең, урталыкта булу – кызның холык-фигыленә хас сыйфат.* Г.Бәйрәмова

3) Билгеле процессның барышында, үсешендә ике арадагы, ике уртадагы этап, аралык. *[Нурия:] Анысы, әлбәттә, шулай. Ләкин бер башлаган эшне төпләмичә, урталыкта калдыруы да шәп түгел бит.* К.Тинчурин. *Гадәттәгечә, берәү тарафыннан кузгатылган сүзгә икенчесе кушылып китми, сүз оешмый, әллә ничек, урталыкта туктальп кала.* Г.Рәхим

4) *иск.* Мохит, тирәлек. *Кичләрен кайный шәһәрдә шау-шу берлә урталык...* Г.Сөнгати. *Гаепләмә, дөнья, урталыкта бәрелә-сугыла үсте бу балаң.* К.Сибгатуллин

5) XX гасыр башында Россиядә, милек хәленә карап, ярлылар белән кулаклар арасында булган катлау. *Ярлылар ачтан үлеп бетте, урта хәллеләр алар хәленә төште, байлар исә тагы да баеп китте. Урталык калмады.* М.Галәү

6) Сәясәттә уң яки сул булмаган карашлар; теге яки бу якны өстен күрмәү позициясе, бер фикернең ялкынлы тарафдары булмау, урта юлны тоту күренеше. *Адәм баласының урталыктагысын шәп түрә ясарлар...* М.Мирза

7) Эштә, карашларда, мөнәсәбәттә һ.б.ш.да чама хисе, такт. *Алтын урталык дигән төшенчә бар.* К.Сатиев. *Һәрбер эштә ниндидер урталык, чама белү дигән нәрсә дә бар бит әле.* Н.Шәрифуллин

**УРТАНЧЫ** *с.* 1) Өч төрле зурлыктагы яки яшьтәге бер төркемгә караган кешеләрнең тәртип буенча икенчесе, уртадагысы. *Гөлбикә – Иманколның уртанчы хатыны.* Т.Гыйззәт. *– Киләчәктә дә марканы төшерә күрмә, – дип, уртанчы абыемның яшьтәше безнең белән саубуллашты.* Ф.Хуҗин

2) *к.* **урта 2.** *Бинаның аскы һәм уртанчы өлеше өч «шакмак»тан гыйбарәт.* Н.Фәттах. *Салып та өлгермәдем, иеме, уртанчы кармакның калкавычы юк бит, әй!* Р.Батулла. *Уртанчы бүлемне башлыча казылык-сыр ише әйберләр басып киткән булып чыкты.* Ф.Бәллүр

**УРТАСЫНА** *бәйл.* 1) Хәрәкәтнең нәрсәнең дә булса урта өлешенә, үзәгенә, кемнәрнең дә булса арасына юнәлгәнлеген белдерү өчен кулланыла. *Сабир сәхнәнең уртасына килеп басты.* А.Алиш. *Үр уртасына җитәрәк, безгә каршы менеп килүче атлар очрады.* А.Гыйләҗев

2) Кемнең яки нәрсәнең дә булса берәр урынның кайсы өлешенә урнашуын, куелуын конкретлаштыру өчен кулланыла. *Рәҗәп әллә каян гына суырып чыгарды да идән уртасына ике ягы да үткенләнгән хәнҗәр кадап куйды.* В.Имамов. *Алай да бакча уртасына урнаштырылган зур прожектор яктылыгыннан биредәге хозурлык апачык күренә.* А.Хәйртдинова

3) Эш-хәлнең нинди дә булса вакытның башы белән ахыры арасында үтәлүен, башкарылуын белдерү өчен кулланыла. *Гомеренең кыл уртасына якынлашып килсә дә, бу – әле аның беренче китабы.* Г.Бәйрәмова. *Шулай, әни белән кыз сукыр лампа яктысында төн уртасына кадәр җеп чорнадылар.* Д.Каюмова

**УРТАСЫНДА** *бәйл.* 1) Эш-хәлнең нәрсәнең дә булса урта, үзәк өлешендә башкарылуын, кемнең-нәрсәнең булу урынын белдерү өчен кулланыла. *Менә шунда, сахра уртасында, Ялтрап тора матур бер күшек.* Г.Сөнгати. *Гаделҗан, нишләргә белмичә, идән уртасында басып тора иде.* Аманулла

2) Кем яки нәрсәнең кешеләр, бертөрле әйберләр һәм күренешләр тарафыннан уратылып алынуын белдерү өчен кулланыла. *Театр училищесы укучылары уртасында Ләләнең тавышы яңгырый.* Г.Әпсәләмов. *Кама аръягында урнашкан Зәй каласы да ноябрь аенда тоташ фетнә ялкыны уртасында калган утрауны хәтерләтә.* В.Имамов

3) Эш-хәлнең теге яки бу вакыт аралыгында башкарылуын, үтәлүен белдерү өчен кулланыла. *Май уртасындагы биш градус суык июнь башларында исә утыз градус эсселек белән алышынды, ышанасызмы?* А.Хәлим. *Нигә һаман шакыйлар соң? Әле җитмәсә, төн уртасында...* А.Мансуров

**УРТАСЫННАН** *бәйл.* 1) Кемнең яки нәрсәнең дә булса берәр урынның, берәр нәрсәнең урта өлешеннән, үзәгеннән хәрәкәт итүен белдерү өчен кулланыла. *Авылның уртасыннан үткән, биек урамнарны кискән, кояш чыгышына киткән бер юл ошбу биек авылны ике бүлемгә аермыштыр.* З.Һади. *Зәйтүнәнең алмадай кызарган ике бит уртасыннан, елмайган иреннәреннән яшьлек бөркелә.* Г.Галиева

2) Эш-хәлнең билгеле бер вакыт аралыгыннан башлануын белдерү өчен кулланыла. *«Кү-кү-кү-күк-кү...» дигән аңлаешсыз санау җәй уртасыннан ишетелә.* К.Кәримов. *Төн уртасыннан*

*соң тәрәзәдә янган ут – киеренке ут: бу өйдә я зур кайгы бар, я – зур шатлык...* М.Вәлиев

**УРТА́ЧА** *с.* **1.** 1) Сыйфаты ягыннан югары булмаган, бик үк яхшы түгел, гадәти. *Укуы да булса булсын Уртача, таман гына.* Л.Шәех // *сөйл.* Бик яхшы да, бик начар да түгел, ярыйсы гына. *Эзләгән йорт уртача, гадәти бер авыл өе булып чыкты.* Д.Булатова

2) Бер ягы белән дә аерылып тормаган, гадәти (кешегә карата). *Бәс, һәр эштә мөгътәдил вә уртача булмак кирәктер.* К.Насыйри. *Сәлимә җиңги артык үткен дә, артык простой да булмыйча, уртача бер хатын иде.* К.Тинчурин

3) Үзенең билгеләре, үзлекләре белән ике чик (зур һәм кечкенә, биек һәм тәбәнәк, авыр һәм җиңел һ.б.) арасында торган. *Мордовиягә уртача континенталь климат хас.* Б.Хәмидуллин. *Учалы – район үзәге, үзенә күрә уртача зурлыктагы шәһәр, монда тирә-яктагы авыллардан яшьләр бик күп.* З.Кадыйрова

4) Берничә зурлык суммасын аларның санына бүлүдән килеп чыккан. *Уртача зурлык*

5) Билгеле күренешләр төркеме өчен гадәти, типик булган. *Рәсми статистика буенча, 12–13 мең сум уртача хезмәт хакы, чын булганда да, хастаханәдәге уртача температура кебек, бернәрсә турында да сөйләми.* Н.Шәрифуллин. *Еллык уртача өлгереш*

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Бик яхшы да, бик начар да түгел, урта дәрәҗәдә. *Әхмәтнең фатиры уртача җыештырылган.* Г.Камал. *Эмилия шәһәрдә әнисе белән генә үсте. Уртача укыды.* А.Нәҗми

2) Урта исәп белән; чама белән, якынча. *Авылларда бер гаиләгә уртача дүрт бала туры килсә, чегәннәрдә алты бала туры килә.* К.Җәмит. *Борынгы кешеләр, тормыш, яшәү шартлары бик авыр булу сәбәпле, бик аз: уртача 25–35 ел гына яшәгән.* Г.Дәүләтшин

**3.** *и. мәгъ.* Укучыларның белемен бәяли торган уңай билгеләрнең иң түбәне; канәгатьләнерлек, өчле. *Чиреккә уртача чыгу. Уртача билгесе*

**УРТА́ЧАЛАНУ** *ф.* Сан яки сыйфат ягыннан уртачага әйләнү

**УРТА́ЧАЛЫК** *и.* Уртача булу сыйфаты. *Гомумән, стандартлык, уртачалык – социализмның иң зур чирләреннән берсе, ахры.* М.Вәлиев. *Хикмәт башкада: чын сәнгатьлелекне уртачалыктан аера белмәүдә, әсәрнең художестволы асылына үтеп кермәүдә, аны уйсыз укуда.* Ф.Хатипов

**УРТЛАМ** *и.* Бер тапкыр уртлап алырлык күләм; йотым. *Уртлам суым әле йотылмаган, Аткан угым сәпкә җитмәгән лә.* М.Кәрим. *Тик нигә әле бүген берәүсен дә Адаштырып миңа китерми? Җан сихәте өстәр бер уртлам чәй Кипкән иренемә тидерми?!* Р.Идиятуллин

**УРТЛАТУ** *ф. йөкл. юн. к.* **уртлау**. *Авыруга бер-ике кашык дару уртлату*

**УРТЛА́У** *ф.* 1) Авыз куышлыгына алу; кабып алып йоту. *Зәринә үрелде. Үз гомерендә беренче тапкыр кыш уртасында каен җиләге уртлады.* Г.Әдһәмова. *Күлдән тотып алып кына учакта кыздырылган багрыдан, өстенә сыр һәм акмай сылап пешерелгән абхаз көлчәсе – хачапуридан авыз итте, шәраб уртлады.* Д.Булатова

2) *диал. к.* **утлау** II. *Менә, малкай, юллар кирәгә таба, әйдә, бахбай, юырт чак кына. Солы уртлап алда ял итәрбез, офыккача җиталсак кына...* Р.Әхмәтҗанов

**Уртлап алу** Тиз генә уртлау; аз гына уртлау. – *Так положено, дустым, – дип, юл аягына тагы бераз самогон уртлап алды да ишеккә юнәлде Володя.* Р.Мөхәммәдиев. *Толя, фикеренең читкәрәк тайпылуын аңлап, алдындагы рюмканы бераз уртлап алганнан соң, --- тынып калды.* Х.Мөдәррисова

**Уртлап карау** Белү, сынау максаты белән уртлау. *Уртлап карагач та мин моны сиздем – кымыз миңа бик күптәннән таныш, әзрәк аера белəм ничегрәк икәнен...* Ә.Еники. *Беркөнне чәйне уртлап карасалар – шыр тоз, авызга алышлы түгел.* Х.Камалов

**Уртлап кую** Бер тапкыр яки аз гына уртлау. *Мин дә ашыкмыйча гына уртлап куям.* Ә.Еники. *Ринат, Илсөягә күтәрелеп карамыйча гына, чәен уртлап куйды.* А.Әхмәтгалиева

**Уртлап тору** Хәзер, әле уртлау; әледән-әле уртлау; озак вакыт дәвамында уртлау. *Шул вакыт арба кырыенда сусыл печән уртлап торган айгыр башын күтәрде, --- пошкырып куйды.* М.Галиев. *[Кәҗә бәтиенең] исем бер дә китми, дип әйтүе булдымы – үзе һаман, сагыз чәйнәгәндәй, авыз эчендә салам уртлап тора.* Р.Мөхәммәдиев

**УРТЛЫЙ-УРТЛЫЙ** *рәв.* Бер-бер артлы нәрсәдер уртлаган хәлдә, уртлап. *Без байтак җирләрдә йөрдек Болгариядә, күп кешеләр күрдек, болгар коньягын уртлый-уртлый, байтак серләр дә сөйләштек...* Р.Фәйзуллин. *Хәлил белән Исмәгыйльнең Эшләре көйле шуңа: Шәраб уртлый-уртлый, алар Бер почмакта кәрт суга.* Г.Морат

**У́РТ ТЕШ** *и. анат.* Аслы-өсле урнашкан яссы өслекле, чәйни торган арткы тешләрнең һәрберсе; азау теш. *Базга су кергән, хатынның бөере авыртып тора, үземнең инде икенче көн урт тешем сызлый, язгы чәчү башланырга тора, ә син юк нәрсә белән теңкәгә тиясең.* З.Хәким. *[Хөрминең] Алгы тешләре бар, урт тешләре урынында кара бушлык иде.* Р.Батулла

**УРТЫН** *с. диал. к.* **урынтын**. *Урынтын юл, уртын юл, ортын юл... Нәкый абзый бу вариантка каршы килде: – Әмма Себер татарлары, мәсәлән, уртын юл дип атыйлар. Анын төп чыганагы «угры» булырга мөмкин.* Г.Бәширов

**УРУ** *ф.* 1) Сабактагы игенне, ашлыкны урак, ургыч, комбайн һ.б.ш. белән кистереп җыю. *Минем угылларым, кызларым шул кызуда урак урып йөриләр.* Г.Исхакый. *Син урасы арышларны көзге җилләр койдымы икән, әллә аларны, ызанда калдырырга жәлләп, чит куллар урдымы?..* А.Гыйләҗев

2) *күч.* Чәлдерү, урлау, шудыру. *Мондый букетны Гаделҗан шәһәрнең берәр бакчасыннан урып кайтты микән әллә?* Д.Гыйсметдин

3) *күч. сөйл.* Күп итеп һәм ашыгып ашау. *Сөтбикәләр силос ура, Шатлык күңелләрендә.* Г.Афзал. *Кәҗәне кәбестә бакчасына кертсәң, урып чыгасын көт тә тор.* А.Хәсәнов

4) *күч.* Дәртләнеп, хисләнеп, оста итеп җырлау, башкару. *Әле менә үткән Май бәйрәме кәнсиртендә «Ай, былбылым» белән «Көймә килә»ләрне шундый итеп урып салдылар, халык аһ итте.* А.Хәлим

5) *күч. гади с.* Тиз һәм йотлыгып уку. *Ә Вәлит яңа китапны урды гына.* В.Имамов

6) *күч.* Күпләп сатып алу. *Тәрәзә пәрдәләрен ура Казан халкы. Заказ арты заказ бездә, апа бәгырькәем!* Н.Гыйматдинова

7) *күч.* Күпләп үтерү. *Карлар ятуга ук, үзенең зәһәр чалгысы белән бәндәләрне урды гына ачлык...* В.Имамов

◊ **Урып салу** 1) Берни дә калдырмыйча ашап бетерү. *Ачәрвах кына гәүдәле булса да, мәҗлес дәвамында бер сарык түшкәсен урып салган чаклары*

*бар.* З.Мәхмүди; 2) Үтереп бетерү. *Бачман --- яланда ике мең башкортны урып салган, диләр.* В.Имамов

**Ура бару** *к.* **урып бару**. *Ура барабыз, суга барабыз, хөкүмәткә тапшыра барабыз.* Кызыл таң

**Ура башлау** Урырга тотыну. *Авыл ягына карадык – бернәрсә дә юк иде, кызып, тагы ура башладык.* Г.Ибраһимов. *Сәдит, җитәкчеләрдән беркем белән дә киңәшми-нитми торып, теге чакрымнарга сузылган загонны кишәрлеккә бүлеп ура башлады.* А.Хәлим

**Ура тору** Берәр эш-хәрәкәт башланганчы, нәрсәдер җиткәнче уру; һаман бер-бер артлы уру

**Урып бару** Рәттән һәрберсен уру. *Керт-керт кенә кистереп, ул миңа таба урып килә, егетләрчә зур-зур чалдырып, дәртләнеп, егетләнеп, мин аңа таба урып барам.* Г.Бәширов

**Урып бетерү** Уруны тәмамлау; булганның һәрберсен уру. *Комбайнчы, йөзе кара, Урып бетереп китеп бара.* Г.Афзал. *Егерме җиденче сентябрь көнне кич, кояш баер алдыннан, бер-бер артлы тезелеп килгән өч комбайн зур басуны урып бетерделәр.* М.Маликова

**Урып бирү** Кем өчендер уру. *Бар, әйт: «Ничек тә булса түләрбез, Бикбулат абзый, болай хәлебез җитмәсә, ашлыгыңны урып бирербез», – диген.* Г.Бәширов

**Урып йөрү** Билгеле вакыт дәвамында уру. *Минем угылларым, кызларым шул кызуда урак урып йөриләр.* Г.Исхакый. *Аннан инде җиләк җыйган таулар, уйнап үскән елгалар, печән җыеп, урак урып йөргән яланнар берәм-берәм аның теленә керәләр, сагынып сөйләнә башлыйлар.* Г.Ибраһимов

**Урып калу** Урырга өлгерү. *Кояш барында урып калырга кирәк.* Р.Батулла

**Урып карау** Белү, сынау максаты белән уру. *Җилләсә, бүген кичкә таба урып карарга була.* Р.Батулла

**Урып китү** Билгеле бер урыннан яки вакыттан ура башлау. *Сәлимәнең сылу буй-сыны да, аның талчыбыктай сыгылмалы гәүдәсе белән иелә-бөгелә җиңел генә урып китүе дә сокланып туймаслык килешле, матур күренә, учмасын салганда миңа кул болгагандай тоела иде.* Г.Бәширов

**Урып кую** Алдан яки тиз арада уру. *Бер-ике көлтә печән урып куйган идем.* Ф.Яруллин. *Байтак кына ризыкны урып куйгач, Мөстәкыйм абзый кулына гармун алды.* В.Имамов

**Урып ташлау** Тиз-тиз яки аннан-моннан гына уру. *Чулак Шәрәфи кырын гына түгел, ярты авыл кырын урып ташларлар әле – җеннәр бит алар...* К.Тинчурин

**Урып тору** Даими яки әледән-әле уру; әле, хәзер уру. *Урып тордылар, таратып киптереп тордылар.* З.Мурсиев. *Озыннарны Урак урып торды, Чүкеп торды Чүкеч шәбрәкләрне.* Ф.Яруллин

**Урып чыгу** Тулысынча, берсен дә калдырмыйча уру. *Аны [арыш бөртеген] уып ашагач, көненә егерме биш сотыйны кул белән урып чыгу – ике тиен бер акча.* М.Мәһдиев

**Урып яту** *сөйл.* Хәзерге вакытта уру. *Кырда чакта бер борчу изә: әлсерәп беткән карт белән карчыкның бөгелсә – билләрен язалмыйча, язылса, бөгә алмыйча, эссе кояш астында, калтыранып, урак урып ятуларын күреп җан өши.* Г.Бәширов. *Авылдан ерак түгел генә басуда урып яталар икән.* М.Вәлиев

**УРУМ** *и.* Азак буе грекларының ике этник төркеменнән берсе: православие динен тоткан, грек телендә сөйләшкән румейлардан аермалы буларак, төрки телдә аралашкан халык һәм шул халыкның бер вәкиле

**УРУ́ МАШИНАСЫ** *и. к.* **ургыч**. *Уру машинасына тракторны җигәсең дә һәммәңнең игенен иңеннән буена эшләп үтәсең.* Г.Ибраһимов

**УРУЧЫ** *и.* Иген ура торган кеше. *Мин уракта, ә Камил абзый лобогрейка белән уручылар янында.* Ә.Салах. *Уручыларны алдан ашату*

**УРЫ́К-СУРЫК** *рәв.* 1) Берьюлы булмыйча, тоташтан түгел, өзеп-өзеп. *[Җәүдәт] эш дигәндә урык-сурык йөрмәде, шырды-бырды кеше белән сүз дә, табын да уртаклашмады.* А.Хәлим. *– Дөрес, улым, – диде Дәүләтгәрәй абзый. – Урык-сурык ат интектереп йөрисе юк.* Н.Фәттах

2) Кайчакта, вакыт-вакыт, анда-санда, ара-тирә. *Аннан соң ул тимерчегә урык-сурык азык җибәрүне дә туктатырга кирәк.* Т.Гыйззәт. *Әмма заказлы эшләр урык-сурык кына булып тора, акчасы уртача яшәргә чак җитә иде.* З.Мифтахов

**УРЫН** *и.* 1) Җир өстендә нәрсә дә булса урнашкан яки урнашырга мөмкин булган өслек, мәйдан. *Әйбәтләбрәк карасам, алпавыт басуының калку бер урынына зур гына ат көтүе килеп менгән икән.* Г.Бәширов. --- *Траншея казырга мөмкин булмаган сазлы урыннарда, крепость стеналарына охшатып, валлар күтәрделәр.* Г.Әпсәләмов // Нәрсәнеңдер элек булган мәйданы, тирәлеге. *Кремль мәйданындагы хан каберләреннән тыш, Тинчурин урамы тирәләре, Киров урамы, иске Университет бинасы тирәсе һәм тагын кимендә 5–6 урын элекке зиратлар бит.* А.Тимергалин. *Октябрь аенда инде авыл урынында тигез мәйдан гына җәйрәп ята, анысы да бульдозерлар белән кырылып, чокылып, асты өскә килеп беткән иде.* В.Имамов // Кем яки нәрсә өчен дә булса билгеләнгән мәйдан, пункт. *Җир казучылар фундамент урынын берсекөнгә өлгертә алмыйлар.* А.Алиш // Яту, утыру, нәрсә дә булса эшләү, башкару өчен махсус билгеләнгән җир, мәйдан. *Шәмсүн Гөлфинурдан күзен алмыйча гына, урыныннан кузгала төшеп, саран ишарә белән аңа урын тәкъдим итте.* А.Вергазов. *Сиңа барысы да күренсен дип, мин тәрәзә янында урын алдым.* А.Азимов

2) Нинди дә булса тирәлекнең бер ягы; җир, төш. *Шул әрәмәлек авызында инде күп еллар сазлыкка әйләнеп яткан бер урын бар.* А.Хәйретдинова. *Бүген качып котыла торган урын юк.* А.Гайнетдинов

3) Берәр вакыйга, хәл булган җир; берәр эш-гамәл турыдан-туры башкарылган җир. *Эшне урында ук хәл итәргә кирәк иде*

4) Оешма, учреждение һ.б.ш.ның югарырак оешмаларга, үзәккә буйсынган структурасы. *Ул заманда әле тәрҗемәчеләрне Мәскәүдән ияртеп килмәгәннәр, гарәп телен белүчеләр урыннарда булган.* М.Мәһдиев. *Урыннарда делегатлар сайлау вә сайланган иптәшләрне Казанга җибәрү эшендә ясалма киртәләр тудырылмасын иде.* Р.Мөхәммәдиев. *Ләкин аны [Коръәнне] башта Ташкентка җибәрәләр --- һәм, изге китапның язмышын урында хәл итәргә, дигән компромисслы карар чыгаралар.* А.Тимергалин

5) Нәрсәнең дә булса аерым үзенчәлекле өлеше, җире. *Өстемә яңа күлмәк кидерделәр, камзулымның төшкән төймәләрен тагып, сүтелгән урыннарын тегеп бирделәр.* Г.Бәширов. *Бары елганың урта бер җирендә, катмый калган урыннан күтәрелгән парны хәтерләтеп, җәяүле буран тузгып тора...* М.Хәсәнов

6) Вакытның, вакыйганың билгеле бер мизгеле. *Бу урында мин сиңа шактый сәер булган һәм минем чәчләрне агарткан хәлләрне сөйләп китәргә мәҗбүрмен, туган.* В.Нуруллин. *Платонның диалогы шушы урында өзелә.* А.Тимергалин

7) Китап, әдәби яки музыкаль әсәр, пьеса һ.б.ш.ның аерым бер өлеше, өзеге. *Мин дустыма китапның иң кызык урыннарын гына укып күрсәтергә булдым.* Г.Бәширов. *Аннары [Данияр журналның] каләм белән сызгалаган урынын тапты да укырга кереште.* М.Хәсәнов

8) Кемнең дә булса җәмгыятьтә, гаиләдә, фән, спорт һ.б. берәр өлкәдә уйнаган роле, ирешкән дәрәҗәсе. *Дөрес, ишү буенча үсмер кызлар арасында район ярышларында беренче урынны яуладым, разряд бирделәр, телевизордан чыгыш ясадык.* А.Гыйләҗев. *Кутуйның әдәбият мәйданында тоткан урынын аның 30–40 нчы еллардагы иҗаты билгели дә.* М.Мәһдиев

9) Вакытлыча яки даими хезмәт итә торган җир. *Районда зур урында эш тәкъдим иттеләр.* А.Нәҗми // Вакансия. *Димәк, бер вакантный урын буш тора.* Г.Афзал

10) Берәр нәрсә хәзер яки кайчандыр булган, шуның эзе калган, яки нәрсә дә булса булырга тиеш дип күздә тотылган җир, төш. *Сәрия, Шүрәленең бер-ике теше урынында тишек караеп торса кызык булмасмы, дип киңәш итте.* А.Тимергалин. *Ут яна операция урыны.* Ф.Садриев. *Җан керергә өлгерми калса, кендек урыны тигез-шома булып кала, имеш. Әлеге баланың Умай мәрхәмәтеннән мәхрүм калуын да шул шома кендек урынына карап белгәннәр.* Г.Гыйльманов

11) Яту һәм йоклау өчен махсус әзерләнгән урын-җир, ятак. *Аннан соң әни урын җәйде дә, без йокларга яттык.* А.Алиш. *Балаларын озаткач ямансулап калган Сания апа өй эчендә әзрәк кыштырдап йөрде дә, урын җәеп, йокларга җыенды.* А.Әхмәтгалиева

12) Берәр эш өчен махсус әзерләнгән әйберләр җыелмасы, корылма. *Янбакчада ике кешелек кенә чәй урыны әзерләнгән, ризыклар кызыл ашъяулык белән пөхтәләп бөркәлгән.* А.Гыйләҗев. *Бу ясалма күл бина эченнән тышкы якка ук чыга һәм җәйге коену урыны белән тоташа.* А.Вергазов

13) Сәбәп, нигез. *Икеләнер урын да калмаган, торырга вакыт!* А.Гыйләҗев. *Табигатькә үпкәләр урын юк.* А.Хәсәнов

◊ **Урын калдырмау** Нәрсәгәдер мөмкинлек бирмәү. *Өлкән туганнары – без, кешеләр тарафыннан, бу килмешәкләр үзләренә оя-нигез кору өчен нинди уңдырышлы чәчүлекләребезне биләгәннәр бит, дип әйтергә урын калдырмыйлар.* А.Хәсәнов. *[Янгуразов] кемгә дә булса сорау биреп торырга урын калдырмады, кырт кистереп үз ниятен әйтте.* В.Имамов. **Урын калмау** Нәрсәнең дә булса кирәге калмау, артык ихтыяҗы булмау. **Урын тапмау** Бик нык борчылу, дулкынлану, нишләргә дә белмәү. *Казан урамында ялгыз шәүлә Үз-үзенә урын табалмый. Күңеленә кунган ап-ак моңы Мөлдерәмә тора – тамалмый...* Г.Гыйльманов. *Йосыф мирза әнә даланы аркылыга-буйга иңләсә дә, үз-үзенә урын табалмыйча изалана.* М.Әмирханов. **Урын тоту** Зур әһәмияткә ия булу, зур роль уйнау, югары дәрәҗәдә булу. *Төркия җөмһүриятенең эчке сәясәтендә төрекчелек зур урын тотты, һәм җөмһүрият төрекчелек нигезендә корылды.* Г.Исхакый. **Урын хастасы** Үз аягында тора алмаслык булып озак вакыт ятып авыручы. *Урын хастасы кешеләр теше-тырнагы белән ябышып яшәргә тырыша.* З.Мурсиев. *Әнкәң ярты ел телсез-авызсыз, урын хастасы булып кузгалмый ятты.* Р.Мулланурова. **Урын өстендә яту** Бик нык яки озак вакыт авыру. *Алланың фәрманы кыска – төнлә паралич сугып, ун көнләп урын өстендә берүзе яткан бу [Байчурин], күршеләре дә абайламаган...* А.Тимергалин. *[Наташа], урын өстендә яткан кайнанасына тагын бер караш ташлап, авыр сулады да тәрәзә янына барып басты.* А.Мансуров. **Урын үгиләү** Күнегелмәгән, ят урында йоклый алмый азаплану. **Урын үзгәләү** *к.* **урын үгиләү**. *[Зиннур] яңадан мендәргә башын салырга өлгермәде, Хәмидә пышылдап сүз кушты: – Син дә йоклый алмыйсынмы? Урын үзгәлисеңдер.* С.Рафиков. **Урыны белән** 1) Кайчагында, кайчак, вакыт-вакыт. *Алар [командирлар] солдатлар янында булырга, урыны белән каты, урыны белән җылы сүз әйтеп, киңәш биреп, авыр походны җиңеләйтергә тиеш иделәр.* Г.Кутуй. *Монда «боргыч» сүзе яңа түгел, урыны белән ул электән үк кулланылгалый иде, тик практикада барыбер рус сүзе йөрүе дә хак.* А.Тимергалин; 2) *к.* **урыны-урыны белән**. *Көннәр-төннәр буенча яуган йомшак карны ерып, урыны белән бөтенләй чума-чума, арткы кеч-кенә фәкыйрь урамга чыкты.* Г.Ибраһимов. **Урыны какшау** Нәрсәнең дә булса дәрәҗәсе төшү, хакимлегенә куркыныч янау. *Партиянең, ыругның элекке җиңелү белмәс куәте кими, урыны какшый, дошманнар көч ала башлаган заман иде.* Г.Ибраһимов. **Урыны килгәндә** *к.* **җай килгәндә**. *Бу газиз нәрсәгә саранланма: урыны килгәндә, белгәнеңне сөйлә. Сүзнең урыны килмәгәндә, яхшы сүзеңне әрәм итмә.* К.Насыйри. *Юнан һәм аның гаскәре – аның диңгез көче икәнен, Аясофья хакында аларның, ай урынына тәре куябыз, дип урыны килгәндә кычкырганнарын аңладым.* Г.Баруди. **Урыны килгән саен** *к.* **җае чыккан саен**. **Урынына утырту** Бик масаеп киткән кешенең һаваланувын нинди дер юл белән киметеп тәртипкә китерү. *Шуның белән артык булдыклы, эшлекле булырга яраткан кешеләрне урынына утырта ул.* А.Хәлим. **Урыны-урыны белән** Тоташ түгел, кайбер урыннарда. *Урыны-урыны белән хәтта ат йөзәрлек җирләре була.* В.Нуруллин. *Гөрләвек сулары яңарак кипкән, тыкрык буйларында урыны-урыны белән яшел үлән төртеп чыккан, яшь кычытканнар тырпаешкан.* А.Гыймадиев. **Урыны чыкканда** *к.* **җай килгәндә**. **Урыны чыккан саен** *к.* **җае чыккан саен**. *Күңелендә Булатка каршы аз гына җылы, яшерен тойгы белән бергә бетмәс-төгәнмәс үпкә дә, шелтә дә бар, урыны чыккан саен, ул аны тыш яктан чәнчеп алырга ярата иде.* Г.Ибраһимов

**УРЫНБАСАР** *и.* Югарырак урындагы вазифалы затның гадәттә аерым бер юнәлештә эшчәнлек алып бара торган, шул вазифалы зат юкта урынына калып, аның эшен башкарырга хокукы булган ярдәмчесе. *Ул көнне зиндан башлыгының урынбасары, камераларда йөреп, тоткыннарны карап чыкканда, Гриша аягүрә каршы алмаган.* Г.Ибраһимов. *Урынбасарның чебен таеп егылырдай шома башында бөрчек-бөрчек тир бәреп чыкты.* З.Мәхмүди

**УРЫН-ВАКЫ́Т КИЛЕШЕ** *и. лингв.* Исемнең эш башкарылуының урынын һәм вакытын, берәр нәрсәдә предметның булу-булмавын белдереп, *кемдә? нәрсәдә? кайда?* сорауларына җавап булып килә торган грамматик формасы. *Урын-вакыт килеше -да/-дә (-та/-тә) кушымчасы белән ясала һәм*

*исемне фигыльгә яки башка сүз төркемнәренә ияртә.* Ф.Хисамова

**УРЫНГА** *бәйл. к.* **урында**. *Ләкин бу өч җан, аска егылып төшәр урынга, ниндидер илаһи, рухи көч ихтыяры белән, күктә очып, хәтта йөзеп йөри башладылар.* Г.Гыйльманов

**УРЫНДА** *бәйл.* Көтелгән, тиешле эш-гамәлне икенче эш-гамәл белән алмашуны белдерә. *Әнисе исә, җавап бирәсе урында, кулындагы төргәген тавышсыз-тынсыз гына сәке өстенә почмакка томырды.* А.Хәлим

**УРЫНДАГЫ** *с.* 1) Билгеле бер җиргә, өлкәгә караган, шул өлкәгә бәйләнешле. *Ерак Харбин шәһәрендәге татарлар (патша жандармериясенең кулы җитми кала) 1914 елда Тукай истәлегенә зур мәҗлес оештыралар. Ни өчен урындагы властьлар тыймый калалар соң?* М.Мәһдиев. *Урындагы материалны, проблемаларны бик яхшы белүче кеше буларак, ВАКта аның [Урмановның] сүзе күп нәрсәне хәл итәчәк.* Р.Вәлиев

2) Мәркәздәге түгел, периферияләге, үзәктән читтә булган. *Эшчеләребез соңгы ике-өч ел эчендә урындагы санаторийларга барырга тырышалар.* Р.Миңнуллин

3) Билгеле бер урында яшәүче; җирле. *Дәүләт җирләрне, хуҗалык итү өчен, урындагы халык (ыру-кабиләләр) карамагына тапшыра, ләкин үз контроленнән ычкындырмый.* Р.Сибәгатов

4) Нинди дә булса хезмәт урынында эшләүче; вазифалы зат булган. *Матур дип, шушы кыз хакына авылда калганчы, урындагы бер урысның кызын кулга төшереп, министр кәнәфиенә үрләү яхшырак булмасмы?* Р.Рахман

**УРЫНДАШ** *и.* 1) Нинди дә булса җыелышта, кичәдә, мәҗлестә урыннары янәшә туры килгән кеше. *Аяк-билләрне бераз язып алыйм, дигән булып, урындашларым яныннан кузгалып, берүзем авыл ягына юнәлдем.* Р.Фәйзуллин. *Килдебеков, җавабының ничек тәэсир итүен белергә теләп, урындашларына күз сирпеп алды.* Р.Зәйдулла

2) *иск.* Яшәү урыннары уртак, янәшә булган иптәшләрнең һәрберсе. *Шәйхи мөәззин кайтып китте, Мәгъсүм мәдрәсәдә калды, Хәмит һәм Вәлид илә урындаш һәм казандаш булды.* З.Һади

**УРЫНДЫК** *и.* Бер кеше утырырлык артлы яки артсыз җиһаз: гадәттә дүрт аяклы утыргыч. *Хат китерүче малай мич буендагы кечкенә урындыкка утырды.* А.Алиш. *Әби үлгәч, бөтен нәрсәсен төяп чыгып киттеләр. Ватык урындыкны да калдырмадылар хәтта.* А.Гыймадиев. *Иләндә ике артсыз урындык, табак, чиләк.* В.Имамов

**УРЫ́Н-ҖИР** *җый. и.* Йокы урыны, йокы кирәк-яраклары; ятак. *Урын-җир җитәрлек, үз туганнарың бит.* А.Гадел. *Ак бина, ак халатлар, ак урын-җир, ак пәрдә, ак түшәм, ак йөзләр, ак чәчләр, ак, ак, ак...* Р.Вәлиев

**УРЫНЛАШТЫРУ** *ф. иск. к.* **урнаштыру**. *Аллаһның фазыйләтеннәндер ки, ул безнең әтрафыбызда аналарыбызны, хатыннарыбызны халык итте вә аларның йөрәкләрендә безгә вә безнең күңелләребездә аларга мәхәббәт урынлаштырды.* Г.Буби. *Русиядә киләчәктә мәмләкәт идарәсе урынлаштырылачак.* Г.Исхакый

**УРЫНЛАШУ** *ф. иск. к.* **урнашу**. *Аның шушы эшләре Казан халкының күңеленә бик нык урынлашкан булганлыгы өчен, алар Сөен-бикәне тиз генә оныта алмадылар.* Һ.Атласи. *Юлчылар, кайсы кайда урынлашып, җыр-музыка тыңларга керештеләр.* Т.Гыйззәт

**УРЫНЛЫ** *с.* **1.** 1) Урыны яки урыннары булган; билгеле сандагы урыны булган. *Ун урынлы автобус*

2) Урын алып торган, урынга ия булган. *Ахун хәзрәт кергәнче, урын таба алмыйча, урынлы кешеләргә көнләшүле күз карашы ташлап, аптырап басып торган берничә мөселман, ахун хәзрәтне олылап каршылагандагы гомум хәрәкәттән файдаланып, кысылатыгызлана, эскәмиядән үзләренә урын алып өлгерделәр.* З.Бигиев

3) *мат.* Берничә яки күп цифр билгесеннән торган. *Һәм менә өч ел элек ул берничә урынлы саннарның квадратын күңелдән исәпләү методикасын уйлап тапкан.* Шәһри Казан

4) Билгеле урында хезмәт иткән, вазифасы булган. *Югары урынлы түрәләр*

5) Кирәк, тиешле вакытта яки урында булган, эшләнгән, әйтелгән һ.б.ш. *Урынлы сүз булса, әйт тә бир...* Г.Кутуй. *Шуңа күрә җырларыбызга багышланган әлеге әңгәмәләр циклын башлап җибәрү урынлы булыр кебек.* И.Юзеев. *Моннан да төгәл, урынлы тостның булуы мөмкин түгел.* А.Гыйләҗев

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Кирәкле, тиешле моментта, шартларга туры килеп яки китерелеп, үз вакытында. *Аһәң бирү өчен, сүзләр урынлы кулланылган.* Г.Ибраһимов. *Мактаганны һәркем ярата, әмма, урынлы тәнкыйтьли белгән шикелле, урынлы мактый да бел.* Р.Низамиев

2) Юкка түгел, билгеле сәбәп яки нигез белән. *Урынлы шикләнә бу, Кавказ якларыннан килеп, башкорт агачларыннан такта ярып йөргән лезчик.* К.Кара

3) Уңышлы рәвештә, отышлы итеп. *Ул сыннарда [кеше һәм җәнлек сыннарында] уймак, көзге, каурый кебек нәрсәләр дә бик килешле һәм урынлы файдаланылган.* Т.Әйди

**УРЫНЛЫЛЫК** *и.* Урынлы булу хәле, сыйфаты. *Тавышымның тигезлегенме әйтерсең, сүзләрнең урынлылыгынмы – һәммәсе аптека үлчәвендә; бигрәк тә мәгънә ягы муаффәкыятьле чыкты.* Ш.Камал

**УРЫНЛЫ́-УРЫНСЫЗ** *с.* **1.** *к.* **урынсыз 1.** *Фәнис профессорның урынлы-урынсыз сорауларына күпме җавап биргәндер, тәкате корыды.* З.Мурсиев

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Урынлымы, түгелме икәнен уйлап тормыйча, тиешсез урында яки вакытта. *«Киленне шулай тоталар аны!» – дип, бу Сабира һәрвакыт Гөлбануны тәнкыйть итеп, урынлы-урынсыз ажгырып тора иде.* Г.Ибраһимов. *Бердәнбер нефтьтән килгән акчаны да урынлы-урынсыз исраф иттек.* Ә.Еники

2) Теләсә ничек, билгеле тәртип белән түгел. *Җиһазлар урынлы-урынсыз кузгатылган. Кием-салымнар теләсә кайда ауный.* А.Гыйләҗев. *Ә ул урынлы-урынсыз яткан әйберләрне бик тиз җыештыра.* Н.Гыйматдинова

**УРЫНСЫЗ** *с.* **1.** 1) Кирәкмәгән, тиешсез, вакытында эшләнмәгән, әйтелмәгән һ.б.ш. *Урынсыз тыйнаклык – башка балта түтәсе.* Г.Әпсәләмов. *Урынсыз шаяртуым өчен, хәтта үземә дә оят булып китте.* А.Хәсәнов.

2) Сәбәпсез, нигезсез. *Тагы --- безнең балаларга чучка ите ашату кеби куркулар – бик урынсыз куркулар.* Г.Исхакый. *Урынсыз гаеп хурландырды бугай, Әнисә бер атна буе аның белән очрашудан качып йөрде.* В.Имамов

**2.** *рәв. мәгъ. к.* **урынсызга**. *Бәс, беркөн бер гакыл иясе болардан сорады: «Ни өчен сез болай урынсыз акча сарыф кыласыз?» – диде.* К.Насыйри. *Кояшның файдалы эсселегеннән урынсыз саклану өчен җиһаз калмаган.* Г.Баруди. *Урынсыз кылынган изгелек урынлы кулланылган усаллыктан яманрак.* И.Гыйләҗев

**3.** *хәб. сүз. функ.* Артык, кирәксез. *Ике йөрәк бергә кушылып типкән чакта, сүзләр урынсыз.* З.Кадыйрова

**УРЫНСЫЗГА** *рәв.* 1) Хак-хокук булмый торып, хаксыз рәвештә, нахак. *Бу дөньяга мәңге килмәгәнбез, Очрап тора җирдә яманы. Урынсызга җанны яралыйбыз, Кичерсәк тә кайчак ялганны.* Р.Зәкуан. *Урынсызга таккан гаепләре Эреп юкка чыкты, аклангач.* Ф.Дәүләтгәрәева

2) Кирәкмәгәнгә, тиешсезгә. *Урынсызга сарыф итү*

3) Сәбәп булмыйча, нигезсез. *Теге көнне мин урынсызга кызып киткәнмен.* Ф.Тарханова

**УРЫНТЫН** *с. диал.* **1.** Яшерен, урау (юл, сукмак тур.). *Мин, кеше очрамаса ярар иде дип, курка-курка гына, кәкре-бөкре урынтын сукмактан атлыйм.* Ш.Маннур. *Байтимер Уразгилдедән караңгылы-яктылыда ук чыгып китте дә, басу капкасын узуга, урынтын юлга борылды.* Г.Бәширов

**2.** *рәв.* Сиздермичә, яшерен рәвештә, астыртын. *Хәерчене урынтын тешләргә теләгән эт кеби, үзе Шәрәфигә каты сүз әйтергә, каты мөгамәлә кылырга хәзерләнә башлады.* Г.Исхакый

**УРЫНЧЫЛЫК** *и.* 1) Гомуми, күмәк эшкә зарар китерү хисабына, урындагы тар мәнфәгатьләрне генә кайгырту; төбәкчелек. *Газеттагы очеркның максаты еракка төбәлгән иде – көчләрнең ни рәвештә урнашуын чамалау, ул, Генераль прокуратура мандаты белән килгәннәргә генә кагылып калмыйча, партия, хокук саклау органнарына һәм башка югары урыннарда утыручыларның уй-фикерләрен ачыклау өчен дә язылды, чөнки аларның күбесе ришвәт, урынчылык, кода-кодагыйлык белән буялып беткән иде.* Р.Мирхәйдәров. *Кешеләрне, урынчылык һәм кардәшырулыктан бигрәк, уртак идея берләштерә икән.* И.Нуруллин

2) Кайбер илләрдә наместник тарафыннан идарә ителә торган административ-территориаль бүленеш берәмлеге; вилаять; *русчасы:* **наместничество**. *Крестьяннар кузгалышыннан коты очкан Әби патша (Екатерина II) 1781 елда Казан губернасын наместниклык («урынчылык») итеп үзгәртә.* А.Тимергалин

3) *лингв.* Телнең аерым бер диалектындагы сөйләшнең билгеле бер территориядә яшәүче кешеләр аралашуында гына кулланыла торган төре; шул территория үзе. *Урынчылык сөйләменең тәрҗемәчеләрне иң нык мавыктырганы – мишәр шивәсе.* Г.Ахунов. *Ләкин шул телдә сөйләшүче халыкларның билгеле бер сөйләшен дикъкать белән күзәткән вакытта, аның һәрбер урынчылыгының үзенә генә хас интонациясе булуын күрергә мөмкин.* Ш.Асылгәрәев

**УРЫНЫНА** *бәйл.* 1) Кем яки нәрсә өчен, шуны алмаштырып. *Декрет ялына чыккач, әнисе урынына эшләп тору мөмкинлеге дә бар.* М.Кәбиров

2) *к.* **урында**. *Күбрәк вакыт ул сүз әйтү урынына сизелер-сизелмәс кенә елмаеп куяр иде.* Б.Рәхимова. *[Гөлшәһидә] төшенде, ләкин күңеле тынычлану урынына катырак борчыла башлады.* Г.Әпсәләмов

3) Кем яки нәрсә белән дә булса чагыштырып әйткәндә кулланыла: шикелле, кебек, сыман. *Рәтен белеп алгач, чаңгыда баруның бер авырлыгы юк аның. Сөлек урынына шуып кына барасың.* В.Нуруллин

**УРЫ́П ҖЫЮ** *и. а.х.* Игенне уру, сугу һ.б.ш. ашлык уңышын җыю эшләре; шул эшләр башкарыла торган чор. *Урып җыю эшләре төгәлләнеп килә, көзге чәчүгә чыгарга әзерләнеп йөри идек.* В.Нуруллин. *Урып җыюның кызган чоры.* Р.Баттал

**УРЫ́П СУГУ** *и. к.* **урып җыю**. *Язгы чәчүне дә, урып сугуны да бик әллә ни теләп эшләми, ач калмагаем дип кенә эшли.* Г.Ахунов

**УРЫС** *и. сөйл. к.* **рус**. *Тигез булды законда Татар, урыс, япон да.* Г.Тукай. *Янәдән Казанга әйләнеп кайткач, мин урыс мәктәбенә татар теле укытырга урнаштым.* Б.Рәхимова

◊ **Урыс атнасы** *диал.* Якшәмбе. *Мәгәр бу хакта бер-бер киңәшкә килергә өлгермәделәр, урыс атнасының икенче көнендә солдатлар тирә-як авыллардагы бар халыкны Сапсал ям станыннан ерак булмаган Талкыш күленә куып йөри башладылар.* Җ.Рәхимов. *Караболак авылында якшәмбене «урыс атнасы» дип йөртәләр, чөнки күрше урыс авылында бу көнне берни эшләмиләр, бәйрәм итәләр.* Ф.Бәйрәмова. **Урыс капка** Юан баганалар утыртылып тактадан ясалган, ишегалдын тоташ каплый торган, күбесенчә кыек түбәле капка. *Хифасулла карт урыс капка ясаган: шундый әйбәт икән, кыегы түбәсенә бер арба печән сыярлык иткән...* А.Гыйләҗев. *Фәһимә үзләренең тәрәзәләрен дә, шыгырдап ачыла торган, кайчандыр әткәсе үз куллары белән ясаган урыс капкаларын да сагынып өлгерде.* Д.Каюмова

**УРЫ́С КӨЯНТӘСЕ** *и. диал. к.* **энә карагы**

**УРЫ́С КЫЧЫТКАНЫ** *и. диал. к.* **сукыр кычыткан** (*2 мәгъ.*)

**УРЫСЛАШТЫРУ** *ф. сөйл. к.* **руслаштыру**. *Мәскәүне дә гаепләмик, әгәр ул барлык халыкларны да урыслаштырырга тели икән – начар ният белән урыслаштырырга теләми.* З.Мәхмүди

**Урыслаштыра бару** Торган саен ныграк урыслаштыру. *Беренчедән, анда балалар аз, икенчедән, телевизор, интернет аларны да урыслаштыра бара.* Р.Зәйдулла

**Урыслаштыра башлау** Урыслаштырырга тотыну

**Урыслаштырып бетерү** Тәмам, тулысынча урыслаштыру. *Үз балаларын да, башка татар балаларын да урысча укытып, милләтне тәмам урыслаштырып бетермәкче, ахрысы.* Безнең гәҗит

**УРЫСЛАШУ** *ф. сөйл. к.* **руслашу**. *Аларның урыслашкан төрки кавемнән булуы ихтимал.* Марс Шабаев

**Урыслаша бару** Торган саен ныграк урыслашу. *Исемнәр дә татарлыгын югалта, урыслаша бара икән бит.* В.Имамов

**Урыслаша башлау** Урыслашу билгеләре күренү. *Әйтик, Себердә яшәүче татар халкы урыслаша башлаган.* Ватаным Татарстан

**Урыслашып бару** Урыслаша башлау, әкренләп урыслашу. *Мондагы нәсел инде урыслашып бара: 90 проценттан артык катнаш никахлар, оныклар урыс телле, аларны әллә кайда калган татар авыллары, аның сандугачлары һәм бакалары кызыксындырмый инде...* Ф.Бәйрәмова

**Урыслашып бетү** Тәмам, бөтенләй урыслашу. *Урыслашып бетте татарлар.* Н.Әхмәдиев

**Урыслашып китү** Билгеле бер вакыттан, вакыйгадан соң урыслашу. *Һәм урыслашып киткән меңнәрчә татар алпавытларын кая куясың?!* М.Хәбибуллин

**УРЫ́С ТӘМНЕКӘЕ** *и. бот. диал.* Иренчәчәклеләр семьялыгыннан кырлы сабаклы, хуш исле кызгылт шәмәхә чәчәкле күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* **шалфей сухостепной**

**УРЫ́С-УЛАК** *җый. и. монг.* Төрле урыслар. *Аны да, урыс-улак белән аралаша, дип сөйлиләр.* М.Галәү. *Басыйр*

*Бариевич – тумышы ягыннан үз ягыбыз кешесе, әнкәсе әле дә исән, Юдинодан ерак түгел ялгыз башы урыс-улак арасында яшәп ята.* А.Гыйләҗев

**УРЫ́С-УНТАГАЙ** *җый. и. сөйл. к.* **урыс-улак**. *Дөньяларның болгавыр чагы, тычканның таяк белән йөргән чагы, ә ул, унҗиде яше дә тулмаган аңгыра бәрән, урыс-унтагай белән аралашып, күзе-башы әйләнеп йөри.* Г.Ахунов

**УРЫ́СЧА** *рәв. сөйл. к.* **русча**. *Ул урысча белми иде.* А.Хәлим. *Профком бухгалтеры Роза апа – урысча сөйләшүе безнеке шикелле – карап-карап торды да: «Пичәт бит ниту», – диде.* А.Хәмзин

**УРЫ́СЧАЛАП** *рәв. сөйл.* 1) Урыс телендә. *Төхфәт тавышсыз гына килде дә, сиздермәстән, кулындагы имән казык белән сугып екты, тагы урысчалап сүгенде.* Г.Ибраһимов. *Капканың теге ягында, урысчалап, ачу белән нәрсәдер әйттеләр.* З.Зәйнуллин

2) Урысларда булганча, урысларга охшатып. *Ә бүгенгә әле Урысчалап кирәк биергә...* Ф.Гыйләҗев

**УРЯ́ДНИК** *и. пол.* 1) 1917 елга кадәрге рус армиясенең казак гаскәрләрендә унтер-офицер дәрәҗәсенә туры килә торган, гади солдатлардан чыккан кече командирлар званиесе; шул званиегә ия зат. *Урядник булып хезмәт итү*

2) 1917 елга кадәрге Россиядә өяз полициясенең түбән чины. *Бишенче көндә доктор, урядник, хөкем иясе килеп җавап алдылар.* Г.Ибраһимов. *Шул, искә төшереп торасы да килми: аю-аю егерме егетнең һәркайсына Усман урядник үзе камчы белән икешәр тапкыр тамызды.* А.Шамов

**УСА́К** *и. бот.* Талчалар семьялыгыннан шома яшькелт соры кайрылы, киртләч яфраклы, уртача яки салкын климатта үсә торган, йомшак үзагачлы агач үсемлек. *Белмим, Әллә күпкә, Әллә бик озакка, Ахры, мәңге оныта алмамын Тамбов урманнары уртасында Усак яфраклары шаулавын...* Һ.Такташ. *Диләнке урынында әнә шулай күп вакыт усак үсә, аның инде, мунчалык бүрәнә булганчы, үзәге бурсый башлый.* З.Мурсиев

**УСА́К ГӨМБӘСЕ** *и. бот.* Болетачалар семьялыгыннан көрәнсу кызыл эшләпәле, кара таплы озын ак аяклы, ак тыгыз итле, усак, каен, имән, нарат, чыршы урманнарында үсә торган ашарга яраклы гөмбә; *русчасы:* **подосиновик**. *Күзләреннән кайнар яшьләре акса акты, әни буласы килеп, ирен сабый белән куандырырга омтылып, толыпка төренеп, усак гөмбәсе ысы астында сәгатьләр буе, буылып ютәлли-ютәлли тиргә манчылып утырды...* А.Гыйләҗев. *Аптырарсың: безнең әти гөмбә танырга бик оста икән. – Монысы каен гөмбәсе, монысы ак гөмбә, монысы таш гөмбә, монысы усак гөмбәсе, бу сарысы майлы гөмбә – табада кыздырып ашарга әйбәт, ә бу шәмәхә битлесен ашарга ярамый, чебен гөмбәсе – агулы, – дип тезеп китте ул.* Ш.Маннур

**УСАКЛЫК** *и.* Усак агачы күп үскән урын, усак урманы. *Усаклыкны егып учак яксаң, Нурлар тигез төшмәс бу чаклы...* А.Хәлим. *Гүли урман, күксел усаклыклар ерак хыял сыман...* Р.Әхмәтҗанов

**УСАЛ** *с.* **1.** 1) Кырыс, аяусыз, мәрхәмәтсез, рәхимсез; явыз. *Ялгышмаса, Платон Платоновичның кызы – гаять холыксыз, тупас һәм усал нәмәрсә, дип сөйләгәннәр иде.* А.Гыйләҗев. *Таһир, сез бик усал кешегә охшыйсыз.* А.Хәсәнов

2) Үч алу, мәкер, дошманлык хисләре белән сугарылган. *Синең кесәңдәге самородоклар иптәшләрең күңелендә усал көнчелек, котырган нәфесләр уята.* А.Хәсәнов. *[Гәүһәр:] Берәр усал ният белән йөридер әле [Зәринә].* Г.Тарханова // Ачу, явызлык, кырыслык белдергән; кискен. *Галия килененең күзләренә усал караш ташлады.* А.Фәләх. *Почмак яктан әнинең: «Тимә балага!» – дигән усал тавышы ишетелде.* Аманулла

3) Кемгәдер, нәрсәгәдер ташланып, чукый, тешләшә, тибешә торган (кошлар, хайваннар тур.). *Усал сыерлар, канауны йимереп, бакчага кереп йөргәнгә, түтәлләр, бакчалар да кешелектән чыкты.* Г.Исхакый. *Каравылчы өчен усал эт – җан тынычлыгы.* З.Мәхмүди. *Татлы хатирәләрдән аерыласы килмәсә дә, усал черкиләрдән котылыр өчен, без өйгә керергә мәҗбүр булдык.* Г.Вәлиева

4) *күч.* Чагылышы, тәэсире белән бик көчле дәрәҗәдә булган; ачы, зәһәр, бик каты (ис, тәм, суык һ.б.ш. тур.). *Сәрвәр абзый кандалаларны өйдән качыра торган нииндидер әчкелтем усал тәмәке көйрәтеп җибәрде.* Д.Гыйсметдин. *Шиңдермәсен усал җилләр безне, Горур, канәгать тот үзеңне.* В.Галиев

5) *күч.* Үткен, чәнечкеле, хәтер калдыра, күңелгә тия торган (сүз тур.). *Җиңүче егет, халыкның усал сүзенә ачуы килгәндәй, сөлгесен кулында бөтерә-бөтерә, күкрәк киереп, мәйдан уртасында айкалырга тотынды.* Г.Бәширов. *Подъезд төбендәге миләш агачында аның [кунакның] усал сүгенү сүзләре генә эленеп калды...* Г.Гыйльманов

6) *күч.* Төртмә телле, чаял, үткер (кеше тур.). --- *Казакъның иң усал тәнкыйтьчесе дә оста каләм белән язылган бу әсәр хакында усал бер сүз әйтмәс, аның тәгъбирләреннән хушланыр иде.* Г.Ибраһимов

7) *күч.* Бәла, афәтләр китерә торган, һәлакәтле. *Усал язмыш йөрткән аларны: илләрен оныттырган, телләрен ташлаттырган, күпчелек ата-бабасының каберен дә хәтереннән чыгарган.* А.Гыйләҗев. *Фаҗигалы очракмы, усал тәкъдирме?* Д.Булатова

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Аяусыз, явыз рәвештә; кызганмыйча

2) Усаллыгын чагылдырып. *Көлүеннән шундук туктап, профессор миңа усал итеп карады.* В.Нуруллин. *Ибраһимның йөзе борыч капкан төсле сытылды, йодрыклары усал йомарланды.* В.Имамов

3) Зәһәр итеп, әче сүзләр белән. *Чалгының куркыныч ягы белән ятуын күргән Маруф абый озын һәм усал итеп сүгенде.* Д.Гыйсметдин

**3.** *и. мәгъ.* Усаллык (*2 мәгъ.*) эшләргә сәләтле явыз кеше. *Әйдә күрсеннәр усаллар, тетрәсеннәр аптырап, Күзләреннән яшь тә түксеннәр, дерелдәп-калтырап.* М.Җәлил. *Чиялеләр – данлыклы усаллар алар.* Р.Батулла. *Арабызда усаллар бар бит. Тешләшәләр. Кешеләргә өрәләр.* Т.Миңнуллин

**УСАЛЛАНДЫРУ** *ф. йөкл. юн. к.* **усаллану**. *Луизаның сабырсызлыгы Рәшатны сизелерлек усалландырды.* А.Гыйләҗев

**УСАЛЛАНУ** *ф.* 1) Усалга әйләнү. *Миннәхмәтнең нурсыз күзләре тагын да усалланган кебек булды.* В.Имамов

2) *күч.* Куәте, интенсивлыгы арту, көчәеп котырыну (җил, дулкын һ.б.). *Җил торган саен көчәйде, усалланды, ахырда тоташ бер үкерүгә әверелде.* Г.Әпсәләмов. *Кырга чыккан саен усаллана барган буран, шул кар өемнәренә менеп, муеннарын боргалый-боргалый улый да, кинәт юашланып, кабат юл өстенә шуышып төшә, аннары, кабат ярсынып, машина тәрәзәсенә килеп сылана...* Г.Гыйльманов

**Усаллана бару** Торган саен ныграк усаллану. *Ул чалгы сабын чытырдатып тоткан, күзләре отыры усаллана бара.* Р.Кәрами

**Усаллана башлау** Усалланырга тотыну. *Бераздан аның татлы тын алуына тышта усаллана башлаган җил тавышы да кушылды.* Н.Әхмәдиев

**Усаллана төшү** Бераз усаллану; тагын да усаллану. *Шундый фикергә килгән Хәдичә тагын да усаллана төште.* К.Тимбикова

**Усалланып алу** Берара гына усаллану. *Катнашучылар арасында бераз усалланып алучылар да булгалый.* Таң

**Усалланып бетү** Тәмам усаллану. *Кырык ел комендант булып эшләгән, кырысланып, усалланып беткән ни зәһәр – ул да аны җәлләде.* Д.Булатова

**Усалланып йөрү** Күптәннән һәм озак усаллану. *Талашырга, үч алырга дип килмәде бит ул. Усалланып йөрмәячәк.* Р.Мулланурова

**Усалланып киту** Кинәт кенә усаллану. *Бу сүзләрне әйткәндә, Михринең йөзе усалланып китте.* А.Нәҗми

**Усалланып кую** Кинәт кенә усаллану. *Ә хәзер, «бәйрәмчеләр» белән тагын күзгә-күзгә очрашкач, тагын аларның эчне тырный торган сүзләрен ишеткәч, ул усалланып куйды.* Н.Фәттах

**УСАЛЛЫК** *и.* 1) Кеше характерына хас усал булу сыйфаты; кырыслык, каты күңеллелек. *Ахыры ничек булып бетәр әле тагын – директор апаның усаллыгы бөтен районга билгеле...* Л.Гыймадиева

2) Берәр начар гамәл, кабахәтлек, әшәке эш, кыланыш, чыгыш; явызлык. *Бала-чага аның шуклык, усаллыкларыннан һәмишә җимерек авыз вә борын белән йөридер иде.* М.Галәү. *Иске идарә, безнең милли хәятымыз башланмасын өчен, кулдан килгән бөтен усаллыкны эшләгән иде.* Г.Исхакый. *Кешегә усаллык эшләүне уена да кертмәгән намуслы карт бу вакытта рәхәтләнеп йоклап ята икән.* Р.Вәлиев

3) Начар ният, әшәкелек, этлек; күңелдәге усал хисләр. *Аның миңа усаллык уйлавын, хыянәтен-фәләнен телгә алырга да мөмкин түгел.* Г.Ибраһимов. *Бу көйсез җаннардагы бөтен усаллык шул бер-ике әрепләшү сүзе белән чыгып беткән иде.* Г.Гыйльманов

4) *күч.* Берәр матдәнең куәте, ачылык, зәһәрлек, катылык. *Спирт усаллыгы Ханбалның ярасын куырып алды, тәне буйлап калтырану йөгерде.* Ф.Яхин

5) *күч.* Тәвәккәллек, карарлы булу сыйфаты; чаялык, үткерлек. *Ниһаять, Зөфәрдә коммерсант усаллыгы һәм мәкерлеге уянды.* Ә.Еники

**УСАЛЛЫ́К КЫЛУ** *ф.* Зарар китерү максаты белән кемгәдер ниндидер явызлык, әшәкелек, этлек эшләү. *Курыкма, Кырмыскак, мин сиңа усаллык кылырга җыенмыйм.* К.Тәхау

**УСАЛТЕЛ** *с.* **1.** Телчән, төртмә телле. *Төхфәтнең хатыны усалтел килен Мәрфуга, аларга ияреп бергә үскән кызлар...* Г.Ибраһимов

**2.** *и. мәгъ.* Каты, чәнчеп сөйләүче; сүзе белән рәнҗетүче кеше

**УСАЛТЕЛЛӘНҮ** *ф.* Начар, тупас сүзләр әйтү, авыр сүз әйтү, чәнчеп сөйләшү. *Фазылның чая хатыны Сания, усалтелләнеп: – Кара инде бу эшем иясләрен! Бер ел эчендә минем нинди әйбәт обоемны эштән чыгардылар бит, – дия иде.* Г.Ахунов. *Механикның нилектән шулай усалтелләнүенең сәбәбен Габделнур чамалый иде.* Р.Кәрами

**УСАЛ-УНТАГАЙ** *җый. и. сөйл.* **1.** Караклар, юлбасарлар һ.б.ш. кебек һәртөрле начар, явыз кешеләр. *– Усал-унтагай очраса? – Курыкмагыз, мин аларга тимәм!* Ш.Галиев

**2.** *с. мәгъ.* Һәртөрле явызлык, усаллык кылырга сәләтле булган. *– Белә, – диде атасы, өздереп. – Белгәнгә шулай күз белән җәзалый, Һашия усал-унтагай хатын. Безне калтыратудан тәм таба ул.* Н.Гыйматдинова

**УСТАВ** *и. рус* 1) Нәрсәнең дә булса үтәлү яки кулланылу тәртибен билгели торган кагыйдәләр җыелмасы. *Ләкин мин, уставны бозып булса да, бу рәсемне үзем белән йөртәм.* Г.Әпсәләмов. *Мин бу майорга бераз Кызыл Армия уставларын өйрәтим әле. Ә хәрби устав буенча безне саклаган солдатлар чыгарырга тиеш.* З.Зәйнуллин

2) Нинди дә булса оешма, учреждение, орган һ.б.ш.ның корылышын һәм эшчәнлек тәртибен, шунда эшләүчеләрнең хокукларын һәм бурычларын билгели торган кагыйдәләр җыелмасы. *Бу – әле бер җәмгыятьнең уставы.* Г.Исхакый. *Икенчедән, ул белеп, колхоз уставы нигезендә эшләнгән.* В.Нуруллин

3) Хәзерге Россиядә, республикаларның конституцияләре аналогы буларак, өлкә, край, федерация әһәмиятендәге шәһәрләр, автономияле өлкәләр һәм автономияле округларның төп законнар җыелмасы. *Чиләбе өлкәсе Уставы*

4) Борынгы грек һәм славян кулъязмаларында кулланылган, хәрефләре авышсыз, шакмаклабрак төшерелү белән аерылып торган язу рәвеше. *Уставны укуы җиңел. Китап устав белән язылган*

**УСТА́ВЧА** *рәв.* Уставта (*1–3 мәгъ.*) күрсәтелгәнчә, устав билгеләгәнчә. *Гатауллин уставча кыска гына итеп рапорт бирде: – Куелган бурыч тулысынча үтәлде.* З.Әхмәтҗанов. *Погоннарыгыз да уставча түгел.* М.Галиев

**УСТАНО́ВКА** *и. рус* 1) Җайланма, механизм. *«Нефтехим»ның иң беренче технологик установкасы 1967 елны сафка керде.* Р.Миңнуллин. *Маллар саву установкасына бер яктан керә тора, сөтен биргәч, икенче яктан чыга тора.* З.Мурсиев

2) *күч.* Нәрсәнең дә булса максат юнәлеше, ниндидер күздә тотылган ориентир; күрсәтмә. *Иртүк өйдән чыгып китәр алдыннан үземә, акча бары тик транспортка гына, дип установка куйган идем.* А.Хәмзин. *Әнә иптәш-әфәндегә минем установка тәэсир итә дә башлады.* Л.Лерон

**УТ** I *и.* 1) Яна торган предметны чорнап алган кызу газлар; ялкын. *Һәлакәткә дучар булган машиналарга ут каба, шартлыйлар.* А.Хәсәнов

2) Кызган күмер һ.б.ш. яндыру, кабызып җибәрү чарасы. *Утка, соскы тотып, күршеләргә йөрерсең.* А.Гыйләҗев. *Үз сәгате белән, кояштан иртә торып, мич алдындагы күмер самавырына ут куеп, күрше килене Зөһрә керткән каймак белән чәй эчеп көнен башламаса, күңеле булмый.* А.Хәйретдинова

3) Янып торган учак. *Өч-дүрт бүре утырганнар каршы утка, Тыршып-тыршып пешермәктә алар бутка.* Г.Тукай

4) Янгын. *Шуңа күрә кызу җәй көннәренең берсендә авылда ут чыгып, байтак йортлар кара күмергә әйләнсә дә, дуңгыз караучы кызның ап-ак итеп агартылган балчык куышы афәттән котылып кала.* А.Тимергалин. *Урамнан кабат ату куркынычы янавын үлчәп-чамалап та тормыйча, --- барысы тиң, ялкын телләре бии башлаган чүпрәкләр өстенә ташланып, утны сүндерделәр.* В.Имамов

5) Табигый яктылык чыганагыннан яки яктырткыч прибордан таралган яктылык. *Пирста сигнал утлары гына яна, чөнки бомбага тотудан куркалар.* А.Тимергалин. *Ай утында урам көрәп йөрим, Ә кар ява, ява ишелеп!..* Г.Гыйльманов. *Тимерҗанны төн уртасына чаклы утны сүндермичә көтеп утырдылар.* В.Имамов

6) *сөйл. к.* **электр**. *[Вахит] өй тирәләрен, ишегалларын, капка төпләрен кар көртләреннән чистартты, поч-*

*тага чыгып, газга, утка түләп кайтты ---.* Г.Гыйльманов

7) Коралдан ату, атыш. *Алга бардылар безнең сафлар Дошман утлары аркылы.* А.Алиш. *Урыс позицияләренә уртадан һөҗүм иткән французларны Семёнов ерганаклары алдында көчле артиллерия уты туктата.* З.Зәйнуллин // Көчле сугыш хәрәкәтләре турында. *Шигырьләрем минем дан күрәләр, Солдат булып утка керәләр...* Г.Кутуй. *Онытыламы соң бергә кан койган, бергә утка, үлемгә кергән сугышчан дуслар!* Г.Әпсәләмов

8) *күч.* Кешенең эчке халәтенең чагылышы буларак күзләрдәге ялтырау. *Зәңгәр күзләрендә ут уйнап торган аксыл бөдрә чәчле бер егет иде ул [Александр].* Г.Әпсәләмов. *Үзенең [Сафуановның] күзләрендә уенчак утлар елтырый иде.* А.Тимергалин

9) *күч.* Кемне дә булса биләп алган көчле хис, тойгы. *Гомернең иң читен, җайсыз, уңгайсыз бер минутында, Әгәр янсам каты хәсрәт вә кайгының мин утында, Укыйм тиз-тиз күңелдән бер гаҗәиб сүрә Коръәннән – Газаплар мәгънәви бер кул илән алынадыр җаннан.* Г.Тукай. *Җирнең карынында Кузгалгач дәһрилек утлары, Биштау булып күккә ашкан дала, Биш өлгесен күкнең куптарып!..* А.Хәлим

10) *күч.* Күңел күтәренкелеге, дәрт, рухи көч. *Уйларым җиңеләеп, яктырып киттеләр, миндә яңа тормыш уты кабынгандай булды. Бу ут алга – каядыр еракка, биеккә дәшә иде.* А.Нәҗми

11) *күч.* Дәртле, энергияле холкы белән аерылып торган, елгыр, үткен кеше. *Егет булса, ут булсын, ут булмаса, юк булсын!* Мәкаль. *Егет булса – мут булсын, Ике күзе ут булсын. Ике күзе ут булмаса, Бар булганчы, юк булсын.* Мәкаль

◊ **Ут алу** 1) Ялкын белән биләп алыну, яна башлау. *Өй эчен ут алды*; 2) Яктырткыч приборны эшләтү, тоташтыру, ут яки учак яндырып җибәрү, кабызу. *Тугайрак урында туктадылар, коры-сары җыйдылар да ут алдылар.* М.Хәбибуллин. *Котдус папиросына ут алды.* Э.Касыймов. *Караңгы төште, авыл ут алды.* Г.Гыйльманов; 3) Югалу, юк булу. *Юлларым буталды, Үткәнне ут алды... Ә мәхәббәт калды.* З.Хәкимуллина; 4) Оялу, дулкынлану һ.б.ш.дан кызарып чыгу, кызышу. *Бу сүзләреннән сон Әзһәрнең йөзен ут алды.* Ф.Яхин; 5) Күңелне борчу, шик, мәхәббәт һ.б.ш. көчле хис биләп алу, тынгылык бирмәү. **Ут ачу** Утлы коралдан ата башлау. *Пушкаларым бердәм ут ачтылар.* М.Хөсәен. *Тизрәк тылга шалтыраттык, тупчылар киртәле торган ут ачтылар.* Х.Камалов. **Ут борчасы (кебек, сыман)** Бик хәрәкәтчән, елгыр, үткен кеше турында. *Өйдә мин, тугыз яшьлек боек бала Рамазан да ут борчасы алты яшьлек Ризуан торып калдык.* Г.Ахунов. *Ут борчасы сыман бөтерелгән күз иярмәслек җитез хәрәкәтле чая кызый ул арада учына тутырган комны тирә-якка сибә.* А.Хәйретдинова. **Ут булып яну** Тән температурасы күтәрелү, кызышу. *Әле җитмәсә, бөтен тәнем сызлый, ут булып яна башлады.* А.Мансуров. *Табан аслары кичкә ут булып яна.* Ф.Садриев. **Ут йоту** Кем яки нәрсә өчен нык борчылу; өзгәләнү, хафалану, хәсрәт чигү. *Мыек төрткән елгыр бер зат өчен ут йоткан чаклары булды инде кызның...* С.Лашманчы. *Үз-үземнән никадәр яшерергә тырышсам да, әниемнең минем өчен ут йотуын, билгесезлектә бәргәләнүен күңел кылым белән сизеп торам.* А.Әхмәтгалиева. **Утка бастыру** *к.* **утлы табага бастыру**. **Ут кабу** 1) *к.* **ут алу** (*4 мәгъ.*). *Үзенең ашыгыч нәтиҗә чыгаруын тойган Мөхәммәтнең колак очларына ут капты.* З.Хөснияр. *Табан астына ут капты, күрәсең, Мөхәммәд шаһ икенче таңда ук Бохараны ташлап чыгып качты.* В.Имамов; 2) *к.* **ут алу** (*5 мәгъ.*); 3) Куркыныч янау. **Утка керү** Белә торып, аңлы рәвештә тормышны куркыныч астына кую; җанын кызганмау. *Җиденчеләре – егерме алтынчы елгы, әле өйләнергә дә өлгермичә утка кергән Әхмәтҗаннарына гына Җиңү көнен күрергә насыйп иткән икән.* А.Хәлим. **Утка коры утын (май) өстәгән сыман булу** Кешене тагын да котыртып җибәрү. *Фәиз өчен исә бу – тагын күңелдәге утка коры утын өстәгән сыман булды: «Нишләп әле ул миннән кача, минем белән утырып бер ярты салырга да теләми!»* З.Хәким. **Ут капкан кебек (капкандай)** 1) Бик эсселәнеп, бик нык кызып. *Каяндыр тирәннән шуңа каршы сукыр ачу дулкыны күтәрелә, куллары йомарлана башлый. Шул дулкын канны кыздыра, бөтен тәненә ут капкан кебек итә.* Х.Камалов; 2) Бик ашыгып, кабаланып, ыгы-зыгы килеп. *Ут капкандай фермадан мастерскойга, аннан кырга, аннан техника паркына чабып йөрүче председательләр хәзер дә юк түгел.* Г.Бәширов. **Утка салу** Тынычлыгын алып, кемне дә булса көчле кайгыга, сагышка дучар итү. *«Әтине үтергән кеше кем? Кайчан тотарлар?» дигән сабырсыз уй каныма ут салды.* Х.Сарьян. *Утларга салырсың, беләм, Калкырмын кабат көлдән! Беләгең тала йөгемнән. Йөрәгең сакла, иркәм!..* Л.Янсуар. **Утка тоту** Билгеле бер нәрсәгә, урынга төрле сугыш коралларыннан көчле ата башлау. *Безнең авиация ул дивизияне маршта чакта ук берничә тапкыр утка тотты, шулай да аның калдыкларыннан шактый зур көч туплануы мөмкин иде әле.* Г.Әпсәләмов. **Ут кебек (шикелле, күк)** 1) Бик кызу, кайнар, эссе. *[Мөдәрриснең] бөтен тәне ут кебек яна, күзен ачарлык та хәле юк иде.* Р.Максудов; 2) Бик чая, үткен; булган, җитез. *Тыштан ут кебек Чистай кызының күңел шәрәфе үзе бер шигъри сафлыктан, нәфис моңнан һәм шигъри ташкын куәтеннән тора кебек.* Р.Туфитуллова; 3) Бик ачык булып, күзгә бәрелеп (ешрак кызыл төскә карата кулланыла). *Күлмәге нинди матур, ут шикелле янып тора. Кайдан алды икән андый күлмәкне?* И.Салахов. *Кич. Эңгер иңеп килә. Әти офыктагы ут кебек янган шәфәкъ яктысына карап тора башлады.* М.Хәбибуллин. **Ут күзле** 1) Кыю, үткен, тере, дәртле карашлы. *Ә үзегез биш ел көтәр идегезме? Сезнең янда ут күзле егетләр урала, ди!..* М.Хәбибуллин; 2) Күпне күрә, тиз күреп өлгерә торган. *Кара туры атлар чаба – ут күзле, Кем күтәрә җирнең йөген – шул көчле!* С.Сөләйманова. *Бу «сукыр тычканнар», җир куенынннан дәррәү күтәрелеп, ут күзле арысланга әверелләр дә тешләрен ыржайтып каршы алалар тегеләрне.* С.Поварисов. **Ут күрше** 1) Янәшә йортта яшәүче. *Әгәр ут күршеңә ут сорап керсәң, аңлармы ул?* А.Хәлим. *Кызып алган ут күрше Хәмит абзый да: – Син, парень, тегеләй-болай геройлык күрсәтергә яратасың, сматри, тегендә эләксәң, сак бул, – ди.* Х.Исмәгыйлев; 2) Янәшә төбәктә, территориядә яшәүчеләр. *Кем әйтмешли, ут күршебез башкорт телендә хәлләр ничек торган соң?* А.Тимергалин. **Ут өермәсе** 1) Төрле сугыш коралларыннан берьюлы ачылган ут, көчле атыш. *Солдат булып, утлар өермәсен Соңгы тапкыр кичкән көнемдә Кайчандыр бер тик төшемә кергән Җәһәннәмне күрдем өнемдә.* М.Садри.

*Әйтерсең лә ут өермәсе, җан иясен генә түгел, табигатьнең матурлыгын да юкка чыгарырга тырыша.* М.Мәхмүтов; 2) Күңелне биләп алган хисләр; хис ташкыны. *Егетләрнең күңелләрендә – ут өермәсе, кызларның күзләрендә, Марсель Гали әйтмешли, «тояк уйный».* Ф.Сафин. **Ут өерту** *к.* **ут уйнату**. *Идарә каршына сары мотоцикл белән, ут өертеп, участок милиционеры килеп туктаган иде.* Ф.Садриев. **Ут салу** Яндыру. *Кайсыдыр салам түбәле өйгә ут салды. Коры саламга эләккән ут дөрләп яна да башлады.* М.Хәбибуллин. *Курсыбай бистәсенә ут салган, үч салган, үч алучы да мин булырмын...* В.Имамов. **Уттан алып суга (бозга) салу** Бер бәладән коткарып, икенче – тагын да зуррак бәлагә дучар итү. *Безне сулардан куганнар «бөек милләт» булганнар, уттан алып бозга салып, чукындырмак булганнар. Уттан алып суга салып – бары чыныктырганнар!..* Р.Әхмәтҗан. *Сынар тәкъдир, сынар азаккача: Сыналып сынмаганны мең кат Уттан алып суга салыр ул, Барыбер өс чыгып калыр ул...* М.Мирза. **Уттан курыккандай** Бик нык, кот очардай булып. *Әмма татар белән башкортның дус яшәвеннән, димәк, нык көчәеп китүеннән урыс түрәләре уттан курыккандай курыкканнар.* М.Әхмәтҗанов. *Уттан курыккандай куркалар бу сырхаудан.* М.Әмирханов. **Утта яну** *к.* **ут булып яну**. *Сафиулла, тәнкәйләрең сызланадыр шул, утларда янасыңдыр, сиңа әйтәм.* А.Әхмәтгалиева. **Ут төртү** *к.* **ут салу**. *Менә бер заман аргы якта югарыга аксыл зәңгәр төтен күтәрелде – аучылар коры камышка ут төрттеләр.* Н.Фәттах. *Уяныгыз, өегезгә ут төртәләр!* А.Хәмзин. **Ут уйнату** Эшнең рәтен белү, бик кызу, бөтен көчне салып, җитез-җитез эш эшләү. *Ичмасам, арка-җилкә рәхәтләнгәнче, киерелеп торып, ут уйнатып эшлисең!* Г.Бәширов. *Басу юлларында, ут уйнатып, тузан өермәсе куптарып, ашлык төягән машиналар чаба.* М.Мостафин. **Ут чыгару** 1) Янгын барлыкка китерү; янгынга сәбәп булу. *Исерткеч эчемлекләр кулланып, ут чыгару нәтиҗәсендә хәрби милекне юк итүгә юл куйган өчен, Рәмзигә каршы җинаять эше ачылу ихтималын ишеткәч, Әлфис, соңгы өмет белән, үзенең взвод командиры янына барырга батырчылык итте.* И.Диндаров; 2) Нәрсәнедер бик кызу һәм оста итеп башкару. *[«Чиравват» Сәйфетдин абый] сугыштан сыңар аягын өздереп кайтса да сынатмый, әнә нинди дәрәҗәле эштә эшли: чут төймәсен йөрткәндә, бармаклары арасыннан ут чыгара, дип сөйлиләр.* Р.Низамиев. *Танылган җырчы, атаклы нәфис сүз остасы, табаннарыннан ут чыгара торган филармония артистлары булмасалар да, гүзәл кызларыбыз, җыелган халыкка үзләренең өйрәнгән шигырь-җырларын, җыр-биюләрен тәкъдим итеп, рухлары нык, күңелләре бай икәнен дәлилләделәр.* Л.Габидуллина; 3) Кискен итеп, бик үткен итеп, ялкынланып, кызып сөйләү; үзәк өзгеч, үтемле итеп башкару. *Ә язларын ничек сайрый иде! «Ут чыгара» иде күкләрдән!..* Р.Әхмәтҗанов. **Ут чыккан кебек (чыккандай, чыкканмыни)** 1) Бик нык ашыгып. *Ул ара да булмый, казан янындагы тирләп, пешеп, кызарып беткән шәкертләрдән берсе ут чыккандай кабаланырга тотынды ---.* Г.Ибраһимов. *Көннәр йөгерә ут чыккандай алга, Кимемәгән тарткан йөгем дә. Дирбиясе чишелмәгән аттай Ятармын мин ауган җиремдә.* И.Беляев; 2) Ыгы-зыгы чыгарып, каударланып, тыз-быз килеп. – *Уф! Котны алдың бит! Ут чыккандай кычкырмасаң... – диде ул [Асилә] ахирәтенә.* Л.Лерон. **Ут ягып** Бик каты, бик нык (кычкырышу тур.). *Таһиянең кыяфәтеннән күренә: ике кодагый ут ягып кычкырышканнар.* Х.Камалов

**УТ** II *и. к.* **үлән**. *Абага чәчәге ут булыр, атып җиткәнче юк булыр.* Мәкаль. *Безнең борынгы бабайлар үләнне «ут» дип йөрткәннәр. Шуннан утар, утлык, утау сүзләре калган.* А.Гыйләҗев

**УТАМАН** *и. диал. к.* **узаман**. *Кызларның утаманы булып егетләр белән сүз көрәштергән дә ул, усал теллесе дә ул.* Г.Бәширов

**УТАР** *и.* 1) Терлекләрне һавада тотар өчен, киртә белән уратып алынган урын. *Тотыш аны-моны абайлап өлгергәнче, ул кире утар ягына карап китте.* Н.Фәттах. *Ахыры сәяхәтенең унҗиденче көнендә дөяләрне утар ягына борырга боерды.* М.Әмирханов

2) *иск.* Гадәттә бай йорты һәм каралтылары булган алпавыт җире, биләмәсе. *Җитмәсә, утар талаудан күрелгән зыянны каплау һәм үтерелгән түрәләрнең гаиләләрен асрау өчен, һәркемгә яңа салымнар салыначак, ди.* М.Галәү. *Утарда көнитешнең бәйрәм, кунаклар, көндәлек һәм хезмәтчеләр катламына караган өлешеннән тыш, дүртенче – башка, астыртын яшәеш: яшерен мәхәббәт, яшерен дуслык, яшерен явызлык дип аталганы бар.* Г.Гайнуллина

**УТА́У** I *ф.* 1) Чүп үләннәрне йолкып, басуны, бакчаны һ.б. чистарту; чүп үләннәрен йолку. *Моны малайга кырык градуслы эсседә иген басуы утаган әнисе өйрәтте.* А.Хәлим. *Шуңадыр инде Ходай үзеннән сәламәтлекне кызганмаган: туксанга кадәр бакчада чүп утады, чебеш-бәпкә белән мәшгуль булды, көтүдән кайткан малларны үз урынына кертеп ябa, хәтта өй эчендә дә кул җиткән чаклы савыт-саба юа иде.* Х.Ширмән

2) Агачның ботакларын кисеп сирәкләү, күпләп сындыру, чәчәкләрне күпләп өзү, кисү. *Аларны аерып була башлагач ук, вакытны сузмыйча, баобабларны [гөләп үсентеләрен] утарга кирәк.* Р.Вәлиев. *Юл һәлакәтенә очрап хастаханәгә эләккәч, Татьяна ханымның бакчасына кереп, бөтен чәчәкләрен утап чыгып киткәннәр.* Шәһри Казан

3) *күч.* Урлап җыеп чыгу яки ашап бетерү. *Әрсез кәҗәләр, караучысыз калган бакчаларга кереп, яшелчәләрне утыйлар.* М.Галәү. *Оятсыз малайлар кыярны утап чыкканнар*

4) *күч.* Күпләп үтерү, кыру. *Хәзер [большевикларның] авыллардагы иярченнәрен дә утарга кирәк.* Т.Гыйззәт

**Утап алу** Тиз генә, кыска гына вакыт утау. *Шуннан чәчәк, яшелчәләр су сорый, түтәлләрне утап аласың.* Татарстан яшьләре

**Утап ату** *к.* **утап ташлау**. *Ялгыш утап атмыйк, Кыраулардан саклыйк Бердәй тойгы-хисне.* Ф.Гыйззәтуллина. *Ә менә шул чүпне утап ату ысулын берсе дә тәкъдим итми.* Безнең гәҗит

**Утап бару** Булган берсен рәттән, эзлекле рәвештә утау. – *Минем казлар бик тырыш: тирә-юньдәге буш яткан җирдәге бер чүпне дә калдырмыйча утап баралар, – ди хуҗа.* Шәһри Казан

**Утап бетерү** Барысын да утау; утау эшен тәгәлләү. *Әти дә эштән кайтты, әнкәй-апалар да чөгендер басуыннан кишәрлекләрен утап бетереп кайттылар.* Ф.Яхин. *Чөгендер җирен утап бетермәкче идем, барыбер калды.* Р.Кәрами

**Утап килү** Акрынлап рәттән утау. *Бәрәңге бакчасын утап киләм, чөгендергә тотынмаган да әле*

**Утап кую** Алдан яки тиз арада утал-ган хәлгә китерү. *Кайткан төшеңә*

*бөтен өеңне утап куярлар!* Ш.Хөсәенов. – *Бер укучы бала, җәйге практикага килеп, үзенә тиешле түтәлләрне актриса Фирдәвес Әхтәмова утап куйганын күреп, шаккатып инша да язган иде, – ди Дания ханым.* Кәеф ничек?

**Утап ташлау** Тиз генә, аннанмоннан утау; ачу, кызулык яки ялгышлык белән утау. *Сез үзегез дә тарыдагы билчәннәрне, сөтле үләннәрне утап ташлыйсыз – игенне болардан тазартасыз.* Г.Ибраһимов. *Түтәл тулы – гел үлән... Утап ташладым барын!* Р.Фәйзуллин

**Утап тору** Гел, һәрвакыт, даими утау; хәзерге вакытта утау. *Бакчадагы чүп үләнне үскән саен утап торган шикелле, әлеге карашларга каршы даими көрәш бара.* С.Поварисов. *Миннән фәкать су сибеп, чүпләрен утап торуны гына сорыйлар.* Г.Галиева

**Утап чыгу** Барысын да яки тулысынча утау. *Утыз сутый бәрәңге бакчасын бер өй бала-чагасы булган ишле гаилә тизрәк утап чыгармы, әллә икеөч бөртек карт пенсионерлар яшәгән гаиләме?* А.Хәсәнов

**Утый башлау** Утарга тотыну. *Гадәттә, дачага килүгә үк, без, күршеләрдән яхшы түгел дип, түтәлләрдәге чүпне утый башлыйбыз.* Шәһри Казан

**УТА́У** II *и.* Чүп үлән; уталырга тиешле үлән; утау (I) эше. *Сигез яшьтән утау утап, унике яшеннән сәнәк тотып үскән кавемнән – бирешергә теләмәде: егылып китәм дигәндә, тәртәгә тотынып өлгерде, соңыннан чана үрәчәсенә ---* Н.Әхмәдиев. *Син инде, остабикәм, аларны язын ашлык чәчтергәнгә, тырма тырматканга, җәен утау утатканга, көзен иген урдырганга, сабан сөрдергәнгә мине битәрләмә ---.* С.Поварисов

**УТАУЧЫ** *и.* Чүп үләннәрен утау белән шөгыльләнүче. *[Нариман:] Уфылдарсың, ерак басуда утаучылар янында идем, аэроплан төшкәнне күргәч, яулыкка чапкан аттай томырылдым.* Т.Гыйззәт. *Утаучы да аның килеп кунганын гына көтә – озынборынны шунда ук юк итә.* А.Алиш

**УТИЛИЗА́ТОР** *и. рус* Нәрсәнедер утилизацияли торган прибор. *ПГУ-60 блогының төп җиһазлары – Швециядә эшләнгән газ турбинасы корылмалары һәм пар казаны утилизаторы.* Кызыл таң

**УТИЛИЗА́ЦИЯ** *и. лат.* Эшкә ярамый торган яки кирәк булмаган нәрсәләрне кабат куллану, чимал буларак файдалану эше. *Машиналар, аларны [чүп-чарны] төяп, утилизация пунктына илтәләр.* Ә.Рәшит. *Казан шәһәре думасы депутатлары бер көн эчендә «Торак-коммуналь хуҗалыгы предприятиесе» ҖЧҖнең әлеге инвестицион программасын һәм чүп-чар утилизациясе өчен түләнәчәк тарифның 2012–2014 елларда артуын раслап та куйдылар.* И.Ядкәрова

**УТИЛИЗА́ЦИЯЛӘ́Ү** *ф.* Ташландык, калдык нәрсәләрне кабат файдалану, файдалы эш өчен куллану. *«Велоигелек» акциясе үз эченә хәйрия, социаль һәм экологик өлешләрне ала, иске һәм кулланылмый торган велосипедларны утилизацияләргә, республикада велохәрәкәт һәм велокультураны үстерергә һәм мохтаҗ балаларга ярдәм итә.* Шәһри Казан. *Һәм, көнкүреш калдыкларын утилизацияләгәнгә бер кеше өчен 22,62 сум түлибез.* Туган як

**Утилизацияләп бетерү** Утилизацияне төгәлләү; барысын да утилизацияләү

**Утилизацияләп тору** Гел, һәрвакыт яки хәзер утилизацияләү

**Утилизацияли башлау** Утилизацияләргә тотыну

**УТИЛИТАР** *с. лат.* 1) Практик әһәмияте, кулланылышы булган; гамәли, практик. *Шулай ук укыту процессында утилитар дидактикадан арындыру да кагыйдә итеп куелды.* А.Әхмәдуллин. *Рецензияләнгән китап үзенең утилитар максатыннан бик ерак тора.* Фән һәм тел // *сөйл.* Көнкүрештәге; көндәлек куллануга яраклы; еш кулланыла торган; функциональ. *Гомумән, борынгы җәмгыять кешеләре өчен әйберләрнең утилитар (көнкүрештәге) вазифасы һәрвакыт өстен булып килгән.* К.Гыйззәтов. *Үз иҗат җимешләрен декоратив (интерьер бизәге буларак) һәм утилитар (көндәлек куллануга яраклы) әйберләргә бүлә ул.* Кәеф ничек?

2) Файда китерүне генә күздә тоткан; утилитаризм белән сугарылган. *Югарыда сөйләнгәннәрдән ачыклanганча, яшәүнең төп чыганагы аучылык булган борынгы җәмгыятьтә тотемистик ышанулар утилитар максатларда зур урын тоткан.* Л.Җамалетдинов. *Ни өчен без нәфес идарә иткән утилитар җәмгыятьнең винтиклары булып, язмышка буйсынып, гомер буе аңа хезмәт итәргә тиешбез соң?* Н.Шәрифуллин

**УТИЛИТАРИЗМ** *и. лат.* 1) *филос.* Кешеләр кылган барлык гамәлләрнең һәм әхлакның нигезендә файда алу омтылышы ята, дигән фикерне алга сөрә торган фәлсәфи-этик тәгълимат. *Шушы сыйфатлары белән К.Насыйри этикасы индивидуалистик һәм эгоистик шәхси файда принцибына нигезләнгән утилитаризм этикасыннан тамырдан аерыла.* Я.Абдуллин. – *Яңа татар әдәбиятында, – ди ул, 1910–1911 еллар әдәбиятын күздә тотып, – хәзер агачка үсеп җитә торган гөмбә шикелле бер паразит бар: ул да утилитаризмның (ягъни тар практицизм, теләсә нәрсәдән турыдан-туры матди табыш алырга омтылу) – менә шул сыйфатның – бик куәтле хөкем сөрүе.* М.Мәһдиев

2) Һәрнәрсәдән матди файда, табыш алырга омтылучанлык. *Бу үз нәүбәтендә газета прозаизмына хас гадиләштерү һәм утилитаризм кебек кимчелекләрдән дә азат булмады.* Г.Халит

**УТИЛИТАРИСТ** *и.* 1) *филос.* Утилитаризм тарафдары. *Шулай ук барлык бәндәләргә дә, кая гына булсалар да, котылу алып килерлек бердәнбер хакыйкать доктринасы, табигый хокуктан яисә изге китаптагы вәхилярдән я даһи кешенең күрәзәләреннән, я гади кешеләрнең табигый акылыннан, я кешелек дөньясына идарә итәргә куелган галим-утилитаристлар элитасының исәпләп чыгаруларыннан торган доктрина турындагы төшенчә дә – шулай ук хата фикер.* Р.Хәкимов

2) Файда артыннан куучы, табыш алырга омтылучы, бөтен нәрсәгә тар прагматик күзлектән чыгып караучы кеше. *[Заһид:] Практик әһәмият турындамы?! Фәндә утилитарист булырга ярамый.* А.Расих

**УТИЛИТАРЛЫК** *и. к.* **утилитаризм**. *Яңа чорга фән-техника тәрәккыяте, утилитарлык хас булачак, дип игълан итеlә.* К.Гыйззәтов

**УТИЛЬ** *и. лат.* 1) Файдалануга яраксыз, кирәксез, ләкин чимал буларак кабат кулланырга мөмкин булган иске-москы әйберләр. *Уенчыклар белән өстәл асты да, караваt асты да тулган, ә бер буш почмакта утиль шикелле өелеп яталар.* Ә.Еники. *Аларны утильдән шушы хәлгә җиткерүче оста Рифгать Ибраһимов самавырда кайнаган чәйнең тәме турында сөйли.* Туганайлар

2) *сөйл.* Файдалануга ярамаган әйберләрне кабат эшкәртүгә кабул итү пункты. *Утильгә илтеп бирү*

**УТИЛЬЛӘШТЕРЕЛҮ** *ф. төш. юн. к.* **утильләштерү**. *Утильләштерелгән машина яңасын алырга ташлама бирә.* Безнең гәҗит

**УТИЛЬЛӘШТЕРҮ** *ф. к.* **утилизацияләү**. *Тик Самосыровода төзелә башлаган яңа «Восточный» полигоны да 10 ел вакыт эчендә тулачак, һәм калдыкларны утильләштерү өчен яңа урын эзләргә кирәк булачак.* Безнең мирас. *2009 елда 922 млн. кубометр газ табылган, 778 млн. кубометры – утильләштерелгән.* Безнең гәҗит

**Утильләштерә башлау** Утильләштерергә тотыну. *Былтыр җыеп алынган машиналарны утильләштерә башладылар.* Туган як

**Утильләштереп бетерү** Барысын да утильләштерү. *Мунча мичендә генә ягып, ул чүпне утильләштереп бетереп булмый.* Кызыл таң

**У́ТКАБЫЗГЫЧ** *и.* 1) Ут кабызу өчен җайланган махсус таш. *Аның гади генә таш түгел, ә уткабызгыч икәнен аңлагандыр дип уйлыйсыңмы?* Р.Вәлиева

2) Электр тогын тоташтыру яки өзү җайланмасы; тоташтыргыч; включатель. *– Вәсилә апа, урам утын ник яндырмыйсыз? – диде кечкенә кунак һәм өйалды кыриена беркетелгән уткабызгычка басты.* Н.Гыйматдинова

3) Ут кабызып җибәрү әсбабы; кабызгыч. *Юмарт «инженер»ның кыйммәтле «Мальборо» сигареты, ялтыравыклы уткабызгычлары кызның күзен бөтенләй камаштырды.* Ш.Шәйдуллин. *Бала шырпы яки уткабызгыч тапкан очракта, бу турыда сезгә әйтергә өйрәтегез.* Хезмәт даны

**УТКОЙРЫК** *и. зоол.* Миләш чыпчыклары семьялыгыннан хәрәкәтчән, җирән койрыклы кечкенә генә сайрар кош; кызылкойрык; *русчасы:* **горихвостка**. *Көн аяз, җилсез, җылы, түтәлләрдә уткойрыклар чүпләнә, бакча башындагы агачлыктан кошлар сайраганы ишетелә.* М.Маликова. *Сыерчык, сандугач, күке, шаулегән, уткойрык һәм башка бик күп кошларны якыннан күрү – гадәти хәл.* З.Бәширов

**У́Т КОРТЫ** *и. зоол. к.* **утлы бөҗәк**. *И юләрләр, ут кортлары ич ул, тапкан икәнсез куркырга әйбер; бүген яңгыр алдыннан шулай күп чыкканнар.* Ак юл

**У́Т КӨЙМӘСЕ** *и. иск.* **пароход**. *[Габденнасыйр:] Идел ага ярын кагып, уңга-сулга чайкалып, Ут көймәсе китеп бара, Сөембикәне алып.* Бәет. *Идел агымына уңгай бер ут көймәсенә утырдык.* К.Насыйри

**УТКҮЗ** *с.* **1.** 1) Игътибарлы, уяу, очлы күзле

2) Кыю, үткер, дәртле

**2.** *и. мәгъ.* Булдыклы, елдам кеше; кыю, тәвәккәл кеше

**У́Т-КҮЗ** *җый. и.* Янгын. *Тәртипле булыгыз, яме, ут-күз чыгара күрмәгез.* Аманулла. *Кешеләр, ишетик, аң булыйк: ут-күз белән сак булыйк.* Идел

**УТЛАВЫК** *и. к.* **утлау** I. *Монда яңадан килгәч, мин сине утлавык читендәге бамбук куаклыгында көтәрмен.* Р.Вәлиев. *Авылда гадәти тормыш кайный башлады: аксакаллар көтүләрне тау утлавыкларына кудылар, хатыннар көндәлек мәшәкатьләргә чумдылар.* Ф.Зариф

**УТЛАНДЫРУ** *ф. йөкл. юн. к.* **утлану**. *Чит кеше кулына килеп эләгүгә борчылыпмы, әллә үзләре туып үскән, хуш исле үләнен ашаган шушы болынкырлардан, алан-урманнардан бөтенләйгә аерылуларын сизенепме, атлар борчылып пошкырыналар, артларына борылып карыйлар, бара торгач, күзләрен утландырып, борыннарын киңәйтеп кешнәп куялар иде.* Г.Бәширов. *Каролина да бу фикерне хуп күреп, күзләрен утландырып, фужерын кулына алды.* М.Хәсәнов

**Утландыра башлау** Утландырырга тотыну

**УТЛАНУ** 1) Ачудан күзләр яну, ялтырау; күзләрдә ачу чагылу. *[Зөлхиҗҗәнең] тулы йөзе кучкылланып кызарган, кара күзләре утланган иде.* М.Әмир

2) Нинди дә булса шатлыктан, сөенечтән яки дәрт-мәхәббәттән күзләр ялтырау; очкынлану. *Госманның рефераты бетәр-бетмәс, кызарган йөз, утланып, шатланып янган күз белән аякка басты, мәҗлесне төрткәләп, Госман янына килде дә рефератчының кулын кат-кат кысты, кочаклап үпте, дулкынланган тавыш белән әйтте: – Мин, – диде, – бүген бәхетлемен, иптәшләр!* Г.Ибраһимов. *Мин өмет утында утланган, Мин сөю суыннан тәм алган ---.* Ф.Яхин

3) Берәр хис-кичереш, тәэсир нәтиҗәсендә бит, тән кызару; кайнарлану; кызыл булып янып тору. *Һаҗәр тагы ялкынлана, тагы күзе томанлана, яңаклары кызарып утлана, иреннәре янып бара иде, инде хәлсезләнеп егылам дигәндә, кисәктән сикереп торды да ишеккә йөгерде.* Г.Ибраһимов

4) *күч.* Ярсу, ярсып китү; ачу чыгу; кызу. *Утланырсың, Уфылдарсың, уйланырсың. Шундыйларны кызганырсың... Шуннан башка ни кылырсың?* С.Кудаш

**Утлана башлау** Утланырга тотыну; утлану билгеләре күренү

**Утланып бетү** Бик нык утлану, тәмам утлану

**Утланып китү** Кинәт утлану, ниндидер сәбәптән, эш-хәлдән соң утлану

**УТЛАТУ** *ф. йөкл. юн. к.* **утлау**. *Көнозын юлда булды, бары тик кич якынлашканда гына атларын утлатырга дип туктады.* М.Хәбибуллин. *Малларны утлатырга җибәргәч, учак ягабыз, чикмәнле бәрәңге пешереп ашыйбыз.* Ш.Маннапов

**Утлатып алу** Аз гына утлату, кыска вакытта утлату. *Дәүран ниндидер инеш янына туктады, атларын утлатып алырга булды.* М.Хәбибуллин

**УТЛА́У** I *и.* Терлекне тукландыру өчен үләне булган урын, утлавык; көтүлек. *Күз алдымда үзәнең якты киңлекләре, тын түбәләре, ак тирмәләре, утлауда йөргән җылкылары белән, кылганлы дала әкрен генә җәелә дә җәелә...* Ә.Еники. *Утлауга барып, эре сөякле, салмак хәрәкәтле чуар сыерларны карап кайттылар.* А.Гыйләҗев

**УТЛА́У** II *ф.* Утлавыкта көтелеп, үлән ашап йөрү (терлек тур.). *Әйдә, курпы утлап, күшәп алырлык тамак ялгап йөреп кайтсыннар.* Т.Гарипова. *Ул утлап килде-килде дә, юлны аркылы чыгып, туп-туры ширкәтчеләр кырына басып керде.* Т.Әйди

**Утлап алу** Аз гына утлау. *Шуннан соң ашказаннарына тутырылган запасны күшәү һәм кичләрен өч сәгать чамасы гына утлап алу дөяләргә юл ахырына кадәр җитә.* Казан утлары

**Утлап тору** Хәзерге вакытта утлау. *Солтанның аты тарантаска бәйләп куйган җирдә печән утлап тора иде, җирән мыеклы Клаус кучерларга – Солтан белән Фатих хәлфәгә – атларны алып, үзе артыннан барырга боерды.* Г.Ахунов

**Утлый башлау** Утларга тотыну. *Шунда кам атка мөрәҗәгать итеп нидер әйтте, һәм хәйран: ат берни булмаган кебек утлый башлады.* М.Хәбибуллин. *Керт-керт итеп маллар утлый башлар. Сискәнерләр каты сөйләшсәң. Вакыт туктап калган кебек*

*булыр, Тау башына менеп чүмәшсәң.* И.Гыйләҗев

**Утлый тору** Әлегә утлау. – *Сыерың ачыккандыр да, арыгандыр да, тынычланып утлый торсын, – дип, атлы арба килгәнче ял итәргә кушып, иярле биясенә атлангач: – Бүренең гәүдәсеннән тиресен үзем тунап алып кайтырмын, мәшәкатьләнеп йөрмәгез, – диде дә җирән биясен юыртып китеп барды.* Л.-Х.Таналин

**УТЛАЧ** *с.* Җитез, кыю, көчле. *Асты-өскә килде замананың: Егетләре кызлар кебекләр. Нәфис затлар нәфис булып калсын, Утлач булсын иде егетләр.* Э.Сафина

**УТЛЫ** *с.* 1) Уты булган, ялкынланып торган, янып торган. *Шулвакыт ул нindidер серле кыяфәт белән үзенә таба карап торган Гасыймның кулында утлы папирос күреп алды.* Н.Фәттах. *Учына утлы күмер салгандай чәбәләнеп, шырпыны сыпыра да төшерә.* А.Вергазов

2) Яктыртылган; якты; балкып торган, җем-җем иткән утлары күп булган. *Нью-Йорк – хәрәкәтле, утлы рекламалар шәһәре.* Р.Батулла

3) Дары яки башка шартлаучан матдәләр кабынып, янып китү нәтиҗәсендә ата торган (корал тур.). *Утлы корал тоткан адәм баласыннан саклана күр.* Г.Сабитов. *Әнә кичә ханның ашчысы сөйләп торды: кайсыдыр мәмләкәттә утлы корал уйлап тапканнар, имеш.* М.Әмирханов

4) *куч.* Дәһшәтле, куркыныч; тыныч булмаган; сугыш бара торган. *Кая киткәнемне әйтмим. Бәлки, Чечнягә, бәлки, дөньяның икенче бер утлы почмагына.* Ф.Яруллин. *Шул утлы көннәрдә менә шушы җирләрдә булган сугышчыларның хәлләрен күз алдына китерәгәч, йөрәкләр жу итеп, тәннәр чымырдап куя.* Р.Мостафин

5) *күч.* Әчетә, яндыра торган, бик куәтле; тәэсир итү көче зур булган (спиртлы эчемлекләр тур.). *Тамагын ярып үткән утлы нәрсәдән чыраен сытып, башларын чайкап, буш стаканны яңадан абыйсы алдына утыртты һәм: – Сал тагын!* Н.Фәттах. *Билал үзенең утлы эчемлеген йотып маташкан вакытта, Шамил аның адресына тагын нindidер ук җибәрмәкче булган иде ахрысы да, әмма Нәсимә: «Ярар, яшьләрне оялтма», – дип, аны туктатты.* М.Вәлиев // Нык тәэсир итә торган. *Чишмәләрнең утлы суын эчәм – Куәт иңә бөтен тәнемә.* Р.Миңнуллин

6) *күч.* Куркыныч; начар, яман. *Нинди утлы хәбәрләр төяп кайттың?* В.Имамов. *Аның баш миен яктыртып, чигәләрен кыздырып, утлы уй йөгереп узгандай булды.* Р.Вәлиев // Борчый, тынгы бирми торган. *Нәрсә эшләргә? Минем башымда хәзер иң нык бөтерелгән утлы сорау шул булды.* М.Вәлиев. *Шулай уенын-чынын бергә кушыбрак сөйләсә дә, йөрәге утлы әрнү белән әрни иде аның.* М.Кәбиров

7) *күч.* Күңелгә тия торган; зәһәр, усал (сүзләр тур.). *Инде Гайфуллага балдызы тарафыннан өстенә яудырылган утлы сүзләрне учына җыярга гына калды.* Ф.Яруллин. *Асаф әнисеннән килгән бер хатның утлы сүзләрен күңелдән белә.* М.Мәһдиев

8) *күч.* Күңелләрне җилкендерә торган; көчле хис, дәрт уята торган, ялкынлы. *Ә төнлә пышылдаган утлы сүзләре, баш югалтырдай булып, шашынып үбүләре, кызны яулап алулары.* Ж.Дәрзаман. *Утлы яшьлек юлларлеген каргап, Күзләремнән күпме яшем тамган.* Г.Батталова // Бик көчле; ярсулы. *Барлык тамырлары, сеңерләре киергедәй тартылган, күкрәгендәге утлы ярсуы уктай атылырга гына торган Тотыш үзенә таш ыргытучыны эзләп тормады – күзенә эләккән беренче угланны тотып алды да, аны да баш аркылы җиргә орды.* Н.Фәттах

9) *күч.* Очкынланып торган; дәрт, көчле хис белдереп торган (күзләр тур.). *Сокланудыр утлы күзләрендә, Моңлы кызганудыр йөзләрендә...* А.Нәҗми

10) *күч.* Ачулы; ялкынлы (караш тур.). – *Минем мондый сорауга җавап бирәсем килми, – диде Габделхәй караңгы чырай белән, утлы күз карашын шешенке күз кабаклы капитанга төбәп.* Н.Фәттах. *Эсселе-суыклы булып, улын утлы караш белән көйдереп алды: шуны да күрмәскә.* А.Хәлим

◊ **Утлы камчы** Яшен яшьнәп күк күкрәү. *Күкләр дә бит рәнҗи беләә: шартлый утлы камчысы.* З.Мәхмүди. *Шул якка табан барып килмәкче дә булган иде, Күк Тәңре утлы камчыларын шарт-шорт шартлата башлагач, кире уйлады, күкрәкчәсенә тегелгән дога-бөтиен капшый-капшый, ашыгып, өенә кереп китте.* Г.Гыйльманов. **Утлы күмергә баскан кебек** Тыныч кына урынында тора алмыйча. *Хәтта һинд мөселманнары мөрәҗәгатьләре укылганда, тыңларга килгән инглиз мөсафиры утлы күмергә баскан кебек булды.* Г.Исхакый. *Утлы күмергә баскан кебек, иртәнге чыкка бармак очлары белән генә баса-баса, караклар кебек як-якларына карана-карана, лагерьдан чыгып киттеләр дә комлы урман юлыннан йөгерешергә тотындылар.* И.Гази. **Утлы күмергә кагылгандай** *к.* **утлы күмергә баскан кебек**. *Кесәсенә ялгыш кулы тиеп киткән саен, утлы күмергә кагылгандай кинәт тартып алды.* Ф.Яруллин. **Утлы күмергә утыргандай** *к.* **утлы күмергә баскан кебек**. *Симиниев, утлы күмергә утыргандай, атылып сикереп торды, шундук кобурасыннан маузерын суырып чыгарды һәм, стена буена – түр бүлмә ишеге ягына тайпылып, коралын коридор ягына төзәп, тычкан сагалаган мәчедәй хәрәкәтсез калды.* Т.Әйди. **Утлы күмер тоткандай** Кабаланып, тиз-тиз, ашыгып. *Гүзәлия кәгазьне утлы күмер тоткандай алды да күкрәгенә кысты.* Ә.Хәсәнов. *Шунда гына мин, утлы күмер тоткандай кабаланып, кулларымны артыма яшердем.* Л.Ихсанова. **Утлы табага баскандай** *к.* **утлы күмергә баскан кебек**. *Әйтәм җирле аталары утлы табага баскандай йөри.* И.Юзеев. *Карчык урынында орчыктай бөтерелде, утлы табага баскандай сикереп-сикереп алгалады.* Ф.Җамалетдинова. **Утлы табага баскан кебек** *к.* **утлы күмергә баскан кебек**. *Принципсызлыкның аргы ягына чыккан бу җитәкченең коты алынган. Ул утлы табага баскан кебек.* Х.Җәләев. **Утлы табага баскан мәче шикелле** Нәрсә эшләргә белмичә, бәргәләнеп. *Френцель, Розенберг дигән сүзне ишеткәч, утлы табага баскан мәче шикелле чабулый башлады.* Ш.Маннур. **Утлы табага бастырган кебек** Бик каты, бик нык (шелтәләү, орышу). *Ветфельдшер Сәлим абыйны утлы табага бастырган кебек кыздыра.* Г.Әпсәләмов. **Утлы табага бастыру** 1) Әрләү; бик каты ачулану, тиргәү. *Замполитның үзен утлы табага бастырырга торалар ди анда.* Х.Камалов. *Синең ише кәҗә тәкәләрен түгел, Шәйхенур Газизовичны утлы табага бастырам, очраса.* А.Гыйләҗев; 2) Күп мәшәкать ясап борчу. *Үз илеңдә ни барын да белмичә, кайларда югалып йөрдең син, юньсез кызый? Бөтен авылны утлы табага бастырдың бит, әй.* Р.Габделхакова; 3) Үч алу, җәзага тарту; кирәген бирү.

*Бу колхозда атларның баш саны пландагыдан аз булуын, шуның өчен райком бюросында әлеге председательне утлы табага бастыруларын да белеп тора.* А.Хәсәнов. *Шул системаның әмерен үтәмәгәннәрнең үзләрен утлы табага бастыралар иде бит.* Ш.Маннапов. **Утлы табада биетү** *к.* **утлы табага бастыру**. *Ник дисәң, ул өзлексез хәрәкәттә: фатир даулап, шәһәр хуҗаларын утлы табада биетә, тулай торактагы буфетларны күз уңында тота, үз бакчасын булдыруны хыялында йөрткәннәргә җир вәгъдә итә.* Т.Галиуллин. *Күрәсең, ул хакимне утлы табада биеткән иде, хаким исә үз чиратында Вәсиләгә эләктерде.* Н.Гыйматдинова. **Утлы хәрефләр белән язу** Беркайчан да онытылмаслык, хәтердән чыкмаслык итү. *Илне фашизм коллыгыннан йолып калу өчен барган көрәш халкыбыз хәтеренә утлы хәрефләр белән язып куелган.* Т.Нәҗмиев

**УТЛЫ́ БӨҖӘК** *и. зоол. к.* **утлы коңгыз**. *Һавада нечкә һәм якты эзләр калдырып, утлы бөҗәкләр очты.* Г.Әпсәләмов. *Утлы бөҗәк тагын да якынайды, һәм аңа аягын читкәрәк алып куярга туры килде.* М.Мусин

**УТЛЫГУ** *ф.* Ачыгудан, артык ябыгудан эчкә батып керү (бит, эч тур.). *[Мәрьямнең] Яңаклары, тиресе итенә ябышып, эчкә утлыгып кергән.* Г.Ибраһимов. *Атның авыр сулаганы ишетелә, утлыкканлыгын эченең еш тирбәнеп торуы да белгертә иде.* Х.Камалов

**Утлыга төшү** Бераз утлыгу; тагын да утлыгу. *Маллар утлыга төшкән*

**Утлыгып бетү** Бик нык утлыгу; тәмам утлыгу

**Утлыгып калу** Ниндидер сәбәптән, вакыйгадан соң утлыгу. *Бите утлыгып калган*

**УТЛЫК** I *и.* Терлеккә азык салып ашату өчен махсус җайланма. *Тезмәдән бер култык тукранбаш печәне алып төшеп, кәҗәнең утлыгына салды.* Ә.Гаффар. *Мал утлыгыннан табып алганнар, хәерсезләр.* Ф.Яхин

**УТЛЫК** II *и.* 1) Самавырның күмер яки шакмак салып ягыла торган, торба рәвешендәге өлеше; күмерлек. *Самавыр утлыгы янса да, чиләк тишелсә дә – төзәтәсе әйберләрен күтәреп, аның янына киләләр.* Т.Нурмөхәммәтов. *Самавырга шул кайнаган суны өстәгәч, утлыгына учактан күмер салды.* Т.Гарипова

2) Мичнең ут яна торган өлеше

3) Мич авызында учакка каршы якта, мичнең кызулыгын саклау һәм күмерләрне тартып кую өчен зур булмаган уем; сукыр учак. *Без кергәндә, ул мич утлыгындагы күмерләрне җыеп маташа иде.* М.Вәлиев

**УТЛЫ́ КОҢГЫЗ** *и. зоол.* Утлы коңгызлар семьялыгыннан төнлә яшькелт төстәге яктылык чыгара торган бөҗәкләрнең гомуми атамасы; *русчасы:* **светляк**. *Утлы коңгызлар килеп, Чыктылар фонарь элеп – Китте дөнья яктырып, Китте дөнья яхшырып!* Р.Корбан

**УТЛЫ́ КОҢГЫЗЛАР** *и. зоол.* Катыканатлылар отрядыннан корсак очында яктырту органы булган бөҗәкләрне берләштерә торган семьялык; *русчасы*: **светляки**

**УТЛЫ́-КЫЗЫЛЛЫ** *с.* Янып торган кызыл. *Тау-тау булып нурланып, утлы-кызыллы, карасу томанлы булып яналар [болытлар].* Г.Ибраһимов. *Әйтерсең алар суыктан шулай утлыкызыллы булып яналар.* Г.Бәширов

**УТЛЫ́-ЯШЕЛЛЕ** *с.* Төрле төсмерләр белән янган яшелле. *Яңгыр туктап беткән, матур гына утлы-яшелле булып, дуга кебек кәкрәеп төшкән салават күпере дә чыкты.* М.Гали

**У́Т НОКТАСЫ** *и. хәрби* Ату өчен туп, пулемёт кебек кораллар куелган урын. *Тимергалиев үзенең расчёты белән дошманның ут ноктасына таба китә.* М.Гыймадиев. *Дошманның ут ноктасы юнәлешенә яшел ракеталар оча башлады.* Г.Әпсәләмов

**УТОПИЗМ** *и. гр.* 1) *филос. к.* **утопия**. *Аерым әсәрләрдә утопизмга авазваш идеяләр дә чагыла.* Я.Абдуллин

2) Буш хыялга бирелү, утопиягә омтылу сыйфаты; утопик карашлар. *Шуның белән бәрабәр ул утопизмга бирелмәде.* Фән һәм тел

**УТО́ПИК** *с.* 1) Утопия (*1 мәгъ.*) тәгълиматына нигезләнгән, шундый асыллы. *Сәхибгәрәй хан вакытында илдә утопик җәмгыятькә туры килешле иминлек, рәхәтлек урнаша.* Х.Миңнегулов

2) Тормышка ашмый торган, реаль булмаган; буш хыялга корылган. *Менә нинди утопик фикер идарә итә аның белән!* А.Әхмәдуллин. *Безнең күңелләребездә яшәгән идеаллар артык утопик түгелме икән?* И.Вәлиуллә

3) *әд. к.* **утопия** (*3 мәгъ.*). *Утопик әсәр*

**УТО́ПИКЛЫК** *и.* 1) *филос.* Утопик фәлсәфәгә нигезләнгәнлек. *Фикернең утопиклыгы*

2) Буш хыялга корылган булу. *Бу – планнарның утопиклыгы өчен түгел.* М.Гайнетдин

**УТО́ПИЯ** *и.* 1) *филос.* Чынбарлыкны һәм җәмгыять үсешенең объектив закончалыкларын исәпкә алмыйча гына яшәешне үзгәртү, идеаль җәмгыять төзү турындагы тәгълимат

2) Тормышка ашмас хыял; фантазия. *Татар милләтчеләренең милли-мәдәни автономиясе төзү турындагы уйдырмасы – коры утопия ул.* Р.Мөхәммәдиев. *Аның хыялы – тормышка ашмаячак утопия: азат, тыныч-рәхәт яшәү.* Д.Заһидуллина

3) *әд.* Тормышта булмаган нәрсәне бар итеп, язучының фантазиясен чынбарлыкта булган кебек итеп сурәтләгән әсәр. *Евроцентризм шартларында, бигрәк тә Рәсәйдә, власть христианнар кулында булып, хөкүмәт ассимиляция сәясәтен алып барганда, Диас Вәлиевнең утопиясе насарилар җиңүе, ислам динен юкка чыгару белән бетәчәк.* М.Юныс

**УТРАК** *с.* **1.** 1) Бер урында гына даими көн иткән, күчмә булмаган. *Татар телендә татар халкының борынборыннан утрак игенче булуын дәлилләгән бик күп сүзләр сакланган.* Р.Әхмәтьянов. *Эстоннар җир эшкәртүче, салкын канлы, утрак халык булганнар.* М.Галиев

2) Бер урында гына даими тормыш алып бару белән бәйле. *Утрак тормышка күчә алыр микән Азат?* А.Тимергалин. *Йөзләгән гектар җирләр мең еллык курган-каберлекләр белән капланган икән, димәк, монда гасырлар буе утрак тормышлы халык яшәгән.* Ф.Бәйрәмова

**2.** *и. мәгъ.* 1) Утрак тормыш белән яшәүче. *Күчмә кабиләләр утракларга һөҗүм итеп, аларны талап качарга да бик яратканнар.* Р.Әхмәтьянов. *Беренчедән, әйтик, аланнар иран телле утраклар булсалар, һуннар аларны биш ел эчендә үзләренә тәмам буйсындырып җитешә алмаслар иде.* М.Зәкиев

2) Даими яши торган урын. *Төркестанда татар-мөселман утракларын да шактый дип әйтәләр.* А.Хәлим. *Борын-борын заманнарда, безнең тирә авылларның басу-кырлары су астында булганда, бабайлар, бөтен әйләнәюньдә беренче сала итеп, хәзерге Калатау урынын утрак иткәннәр.* М.Хуҗин. *Утракларын ташлап китүчеләр дә бар.* Кызыл таң

**УТРАКЛАНУ** *ф.* Утрак хуҗалык итү рәвешенә күчү, утрак тормыш белән яши башлау. *Алар монда җирле халыкларны, шул исәптән үзләреннән элегрәк килеп утракланган төрки кабиләләрне буйсындыралар.* Н.Фәттах

**УТРАКЛАШУ** *ф. к.* **утраклану**. *Оешу, утраклашу һәм күбәю тарихлары шактый үзенчәлекле булган алтайлы татарларның көнкүрешләре, горефгадәтләре белән телләре дә гыйбрәтле эволюция кичерә.* М.Госманов. *Бу хәл элекке ярымкүчмә тормыштан утраклашып көн итүгә күчү белән бәйле.* Р.Фәхретдинов

**Утраклаша башлау** Утраклашырга тотыну. *Нәтиҗәдә, Сергач төбәгендәге авылларның бер төркем кәсепче игенчеләре берәм-берәм Финляндиягә күченеп, шул илдә җирләшә, утраклаша башлый.* Г.Таһир

**Утраклашып бетү** Тәмам утраклашу; утракка әйләнү

**УТРАКЛЫК** *и.* Утрак тормыш. *Соңгы елларда күчмәлектән утраклыкка күчү гомумән зур көч алды.* И.Хуҗин. *Мәшәкатьле күчмә тормыштан утраклыкка күчүнең бер билгесе булып калыккан мәһабәт таш диварлар, биек манараларның кояш нурларында балкуын күреп шатланганнардыр.* И.Диндаров

**УТРАКСА** *и. анат.* Кеше гәүдәсенең утыра торган өлеше; арт сан; *русчасы*: **седалище**. *Үсмер егетне йөзтүбән каплагач, якын-тирәдәге бөтен кеше аһ итте: аның ике утракса бите кисеп алынган иде...* Р.Кәрами. *Үкчәләрне утраксага мөмкин кадәр якынрак китереп, аякларыгызны тездән бөгегез.* Якты юл // Хайваннарда арткы очлык поясының бер өлеше. *Арткы очлыклар поясы парлы оча, утракса һәм касык сөякләреннән тора.* Биология

**УТРА́У** *и.* 1) Океан, диңгез һ.б.ш. су уртасында урнашкан коры җир. *1962 елда Төньяк Боз океанындагы бер утрауга татар егете Фәхри Хәйруллин исеме бирелде.* А.Тимергалин. *Минем дә тәмле ашыйсым, матур киенәсем, Гавай, Канар утрауларында ял итәсем килә.* З.Мәхмүди // Елга яки күл эчендә һәр ягыннан да су уратып алган кечкенә коры җир; атау. *Кама елгасындагы утрауда, безнең авылдан утыз километрда, колхозның илле җиде гектар болыны бар барын.* В.Нуруллин

2) *күч.* Тирә-юньдәгеләрдән читтәрәк булып, берникадәр аерылып торган территория. *Хәлил чыгарма булып, ягъни үзенә бер коммунистик утрау булып кала бирде.* Т.Галиуллин. *Әлбәттә, тирә-якта бәяләр күтәрелгәндә, Татарстан гына утрау булып кала алмый.* М.Галиев

**УТРАУЛЫК** *и.* Утраулар төркеме яки тезмәсе. *Утраулыкларны өйрәнү*

**У́Т-СУ** *җый. и.* Ут һәм су. *Ахырда, сүндереп, ут-суны карап чыгып киткәнлеген хәтерләп тынычланды.* Ф.Җамалетдинова. *Анысын әйтәсе булмаган икән, шул сүз карчыкка ярсып китәргә җитә калды, әлегәчә тыныч йөзе җыерылып китте, бәсле кашлары арасына кай арада нәфрәт кошы килеп кунды: – Ут-суга да түләп бетермәле түгел, пинсенең яртысы шунда китә.* Р.Габделхакова

◊ **Утка-суга керү** Мөмкин булганның барысын да эшләү; кем яки нәрсә өчен бөтен авырлыкларга да түзү, бик нык тырышу. *Ул балалары хакына утка-суга да керә торган, бик тырыш кеше була.* Т.Нәҗмиев. *Һәр тере җан мәшәкатькә чума, оя кора, нәсел дәвам итү өчен утка-суга керә.* Г.Якупова. **Утка-суга төшү** *к.* **утка-суга керү**. *Янгураз өчен мин дә утка-суга төшәргә дә, гүргә керергә дә әзер идем.* Р.Габделхакова. **Утны-суны кичү** Төрле кыенлыклар күрү, бик күп авырлыклар кичерү; сынаулар аша үтеп чыныгу. *Утны-суны кичкән һәм кешелеген саклап калган, дип сөйлиләр.* А.Тимергалин. *Намуслы татар хатыны, көн дә йөзләгән баланың күзенә карап намус, вөҗдан төшенчәсен бәйнә-бәйнә аңлатучы укытучы, гаиләсе өчен дә, кызлары өчен дә йөрәге белән кайгырып, утсу кичте бит!* М.Әхмәтшина

**У́Т ТАВЫ** *и. к.* **вулкан, янартау**. *Сугыш үзе моннан ерак булса да, кызарып кояш батканда, шәфәкъ алсулыгы җәелгәндә, ут таулары атылган җәһәннәм төсле тоелып, йөрәккә шом сала.* С.Лашманчы

**У́Т ТАШЫ** *и. иск. к.* **чакматаш**. *[Сусылның] Үз сараеның стенасы тулы ут ташы!* Р.Хафизова

**УТЧӘЧӘК** *и. бот.* Казаякчалар семьялыгыннан вак яфраклы, сары чәчәкле, тәбәнәк кенә сазлык үсемлеге; *русчасы:* **лютик болотный**. *Утчәчәк иде ул [Фәрәхшат], янарчәчәк!* Р.Төхфәтуллин. *Берсе сүнсә, балкыр тагын берсе, Янар яңа йолдыз – утчәчәк.* Кызыл таң

**УТЧЫЛ** *и. зоол. к.* **утчыл күбәләк**. *Крыжовникны утчыл дип аталган кортлар бик ярата.* Сөембикә

**УТЧЫ́Л КҮБӘЛӘК** *и. зоол.* Корты үсемлекләргә зарар китерә торган кечерәк кенә күбәләк; *русчасы:* **огнёвка**. *Иртә язда, бөреләр чыкканчы, утчыл күбәләктән зыян күргән карлыган белән крыжовник куаклары өстенә 60 градус кайнарлыктагы су сибәргә кирәк.* Шәһри Казан. *Июнь аенда утчыл күбәләкнең кортлары җиргә төшә, туфрак астына шуышып керә һәм шунда курчакка әверелә.* Кызыл таң

**УТЧЫЛЛАР** *и. күпл. зоол.* Тәңкәканатлылар отрядыннан күбесенчә дала һәм чүлләрдә очрый, авыл хуҗалыгына зарар китерүче күбәләкләрне берләштерә торган семьялык; *русчасы:* **огнёвки**

**УТЫЗ** *сан* 30ны белдерә торган сан атамасы. *Утыз ел туку станоклары арасында үткән вакыт аңа бик кыска булып тоелды.* А.Алиш. *Белмәсәң бел: миңа тиздән утыз яшь тула, балакаем!* Т.Миңнуллин

◊ **Утыз тугызлы** Акылга тулы булмаган, җиңел холыклы. *Өйләнсәләр дә, балалары утыз тугызлы булып туа.* Ватаным Татарстан

**УТЫЗАР** *сан* Нәрсәгәдер бертигез күләмдә утыз туры килүне белдергән бүлем саны. *Һәрбер паспортка утызар тәңкә түләсәләр, бүтән чыгымнар өчен аларның бер тиен акчалары калмаячак иде.* М.Галәү. *Бушатырга егермешәр, утызар машина килеп тезелә, атналар буе көтәсең.* К.Кара

**УТЫЗЛАП** *сан* Чама белән утыз, утызга якын булуны белдергән чама саны. *Мунчада кеше аз ич, пар бүлмәсе бик зур, анда берьюлы утызлап кеше кереп җылынырлык.* Б.Рәхимова. *Ә бит сугыш алдыннан гына коллективка утызлап кеше җыелган, аның яртысын өрлектәй егетләр тәшкил итә иде...* А.Әхмәтгалиева

**УТЫЗЛЫ** *с.* Күләме, зурлыгы, үлчәме һ.б.лары 30 санлы булган (мәс., аяк киеме, җеп һ.б.). *– Шулай булгач... шулай булгач, – дип кабатлап торды да, кинәт, янәшәсендәгеләрне сискәндереп, һич көтмәгәндә, чалышма аяклы өстәлнең утызлы такталарына авыр йодрыгын төшерде.* Г.Кашапов. *Чулпания кинаяле генә елмайды да, дөрли башлаган утызлы лампаны кыса төшеп: – Әллә ошадымы? Баягынак серләрегез бик килеште кебек... – дип сорады.* М.Хәсәнов

**УТЫЗЛЫК** *и. сөйл.* Утыз сумлык, утыз сумга йөри торган кәгазь акча.

*Аларның акчалары унлык та утызлык, йөзлек.* Н.Фәттах. *Тагын бер утызлык аның кулына килеп керде.* М.Мәһдиев

**УТЫ́ЗМЕҢЧЕ** *и. тар.* 1955–1957 елларда, партия чакыруы белән, шәһәр предприятие һәм учреждениеләреннән икътисади яктан артта калган күмәк хуҗалыкларга җитәкчелек итү өчен җибәрелгән 30 мең алдынгы хезмәткәрнең берсе. *Илленче еллар ахырында колхозларга утызмеңчеләр дигән җитәкче кадрлар килә башлагач та, Мөбарәкша үз сүзен сөйләде: – Аның авылда туып үскәненә сүз дә әйтмим, алары эшли дә алыр, ну да бит шәһәр кешесен авылга җибәрәләр.* М.Мәһдиев. *Утызмеңчеләр чорында Әхмәдиевне колхоз рәисе итеп куялар.* М.Галиев

**УТЫЗЫНЧЫ** *сан* Бер-бер артлы санаганда урын тәртибе утызга туры килүне белдергән тәртип саны. *Утызынчы апрельдә биш кыз, биш малай ерак урманга бардык.* А.Гыйләҗев. *Шул репрессияләр башланыр алдыннан, утызынчы еллар уртасында булган күңелле балык тотулар, уха пешерүләр кебек еллар минем тормышымда башка булмадылар.* З.Зәйнуллин

**УТЫН** *и.* 1) Ягар өчен кисеп һәм ярып махсус хәзерләнгән агачлар. *Утын кисеп өйрәнгән нык беләкле малайлар өчен ишкәк ишүнең авырлыгы сизелмәсә дә, җаена төшенәсе булды.* А.Тимергалин. *Фәһим абыең менә кичә генә бер арба утын кайтарып аударган, рәхмәт төшкере.* А.Әхмәтгалиева

2) *күч.* Мәгънәсез, аңгыра кеше; хәшәп. *[Сәүдәгәр спекулянт] Базга күмгән акчаларны, өскә кигән иске тун! Бер фәкыйрь булган, имеш, танытмый ягъни, и утын!* М.Җәлил

◊ **Утын вату** Зур ялгышлык эшләү, нәрсәне дә булса төзәтеп булмаслык итеп бозу. *Сез, күрәсең, үзегезнең дуамаллыгыгыз аркасында җитәрлек утын ваткансыз!* А.Расих. *Бу – кешене күп вакытта урынсызга «утын ватулардан» коткара.* Шәһри Казан. **Утын түмәре** *туп.* 1) Кыска буйлы, юан, авыр хәрәкәтле, әкрен кыймылдаучан кеше; 2) Булдыксыз, аңгыра кеше. *Җизнинең утын түмәре икәнен белә идем инде, әмма, апа, сине болай колхозның миңгерәү сарыгына әйләнгәнсеңдер дип уйламый идем.* Ф.Яруллин. *Иптәш кызлары аларны укыгач кычкырып көләләр: «Бу бит егет түгел, утын түмәре», – дип, Гөлзаданың эчен яндыралар иде.* Ф.Садриев. **Утын түмәркәсе** *к.* **утын түмәре**. *Әллә ниткән бер утын түмәркәсе – токтомалга дәү, ни селкенә, ни көрәшә белми торган аю Арсланның ике тапкыр өстенә төште.* Г.Ахунов. **Утын түмәрләре кебек** Селкенмичә; тик кенә, җыр-биюгә кушылмыйча. *Яшьләрнең бу дәртле җыры шулкадәр биләп алган иде кунакларны, утын түмәрләре кебек утырган абзый һәм апалар да түзмәде, урыннарыннан сикереп-сикереп тордылар.* Р.Мөхәммәдиев

**УТЫНЛЫК** *и.* **1.** Утын киселә, ярыла, өелә һәм саклана торган урын, сарай. *Бәхетенә күрә, утынлык ишеге яртылаш ачык, көрәк, себерке дә шунда икән.* М.Хәсәнов. *Ә бүген иртән утынга дип чыкса, утынлык ишегенең йозагы ватык, ди.* Ә.Мушинский

**2.** *с. мәгъ.* 1) Утынга китә торган; утын итеп кулланылачак (агач тур.). *Хәзер үк сезгә бер трактор утынлык агач китерергә кушармын...* Л.Лерон. *Утынлык каен. Утынлык бүрәнә*

2) Утынга дигән, утын алырга тотарлык. *Спектакль чыгымнарыннан арткан акчага бер пот ак он, сары май, йомырка, сарык ите, дөге ярмасы, кер сабыны, егерме метр мануфактура алып, Камал өенә китерәләр. Шулар өстенә утынлык акча да калдыралар.* Р.Батулла

**УТЫНЧЫ** *и. иск.* 1) Утын белән сату итүче кеше. *Ул, чабатадан түгел, чабатасыз, хәтта ыштансыз килеп, Оренбургта харчевняда савыт-саба юучы булудан башлап, хәзер Урал буеның иң зур утынчы, бүрәнәчесе булды.* Г.Исхакый. *Әле утынчы, әле күмерче, әле сучы, акча сорап, теңкәне корытып бетерә.* Г.Камал

2) Утын кисүче, утын кисеп ташучы. *[Каюм:] Утынчы буласың килсә, билгеле, утын яру файдалы.* Г.Исхакый. *Кызның дәшмәвен күреп, сүзен дәвам итә утынчы: – Агачны аудырырга гына җыенган идем, сине күреп, әллә күктән фәрештә иңдеме дип торам?* Н.Сәйяр

**УТЫРГЫЧ** *и.* 1) Утырыр өчен махсус эшләнгән, ясалган урын. *Апак мәһабәт колонналар каршындагы ярымтүгәрәк утыргыч аның иң яраткан урынына әверелде.* Г.Әдһәмова. *Казанда яши башлауларына бер ел дигәндә, яшьләргә Кабан күле буендагы һәр утыргыч, һәр агач таныш иде инде.* Г.Исхакова

2) *сөйл. к.* **урындык**. *Шулчакны арткы рәттә утыргыч шыгырдап куйды, һәм шыпырт кына атлаган аяк тавышлары ишетелде.* А.Тимергалин. *Сафия йодрыгы белән шап-шап утыргыч кыйнады.* Н.Гыйматдинова

3) *күч. сир.* Хезмәт урыны. *Бәлки, Гыйльман старшинаның утыргычы алдагы көннәрнең берсендә Хәмәй картның утырганын көтә торгандыр?!* Х.Кәрим

**УТЫРДАШ** *и.* 1) Әңгәмәдә, сөйләшүдә катнашучы, кем белән дә булса сөйләшеп утыручы; гәптәш. *Мин бу вакыйгадагы бер хәлнең шаһиты, ягъни капка төбендәге әңгәмәдә утырдаш булдым, яшь аралары шактый аермалы икәүнең мәхәббәт уты Айдай зураеп кабынуын да шунда күрдем бит.* М.Хуҗин. *Сәйдәш белән утырдаш, әңгәмәдәш булуны һәркем үзе өчен хөрмәт һәм горурлык саный санавын.* Р.Низамиев

2) Нинди дә булса массакүләм чарада катнашучыларның, янәшә утыручыларның берсе; мәҗлесләрдә бергә утыручы. *Без аның белән төрле фәнни семинарларда утырдаш булдык, фикердәш идек, бер-беребезгә кунакка йөрештек, ризык бүлештек...* А.Гыйләҗев. *Әйтик, кунак-кунак уйнамадык, даими утырдашлар да булмадык.* Ю.Сафиуллин

**УТЫРДАШЧЫ** *и. ялг. к.* **утырдаш**. *Утырдашчылар, яңа гайбәтләрне уртаклаша-уртаклаша, бер самавыр чәй эчеп бетерделәр.* М.Галәү

**УТЫРМА** I *и.* **1.** Сыеклыкта, эремәдә нинди дә булса матдәнең төпкә утырган вак кисәкләре. *Бораулау юка гына ком һәм кызыл балчык катламыннан соң, чыннан да, тиз юыла-ашала торган токымнар: көпшәк утырмалар белән аралашкан известьташ һәм гипс ятуын күрсәтте.* Р.Мостафин. *Түшәмендә боз сөңгесенә охшатып ясалган сталактитлар (су саркудан барлыкка килгән известь утырмасы) эленеп тора.* Шәһри Казан

**2.** *с. мәгъ.* 1) Төпкә утырып, катлам булып торган. *Утырма ком. Утырма балчык*

2) *геол.* Минераль һәм органик матдәләр утырып, аларның әкренләп тыгызлануы һәм үзгәрүе аркасында барлыкка килгән. *Утырма катламнарда тимер рудасы, төсле металл, нефть, табигый газ запаслары табылды.* Материклар һәм океаннар географиясе. *Сульфатлар төркеменә кергән минераллар утырма тау токымнарын оештыруда катнашалар.* Төзү материаллары

**УТЫРМА** II *с. к.* **утырмалы**. *Утырма көзге итәгендәге киштәгә меңмиллион төрле вак-вак шешәләр тезелгән иде.* А.Гыйләҗев

**УТЫРМА** III *с.* Кайтарып куелмый торган; турыга бастырып куелган; төз. *Ул озынчарак буйлы, арык йөзле, башына каракүл бүрек, өстенә утырма якалы зур кара толып, аягына сары бурка белән резинка калуш кигән.* Г.Ибраһимов // Туры басып торган; өскә таба караган. *Кыргый мәктән аермалы буларак, озынча, эре, утырма яфраклары балавызсыман элпә белән капланганнар.* Агулы үсемлекләр

**УТЫРМА** IV *и. этн.* 1) Хатын-кызларның дус-туганнары, күршеләре һ.б.ш. белән җыелып, озаклап кунак булу йоласы (гадәттә чигү, бәйләү һ.б. кул эшләре башкару өчен җыелганнар). *Без бит, үзең беләсең, утырма кызлары шикелле, кунакка да эш белән йөрибез.* Н.Нәҗми. *Имеш, беркөнне кемгәдер барып кергән бу, ә анда кызлар утырмага килгән: сәке йөзлегенә тезелеп, бәйләп-чигеп утыралар икән.* М.Маликова. *[Атасы Бибимәмдүдәгә:] – Йоннарыңны эрләп куй, утырмада оекбиялэйләр бәйләп кайтырсың, – диде.* М.Әмирханов

2) Яшьләрнең, төрле уеннар уйнап, сөйләшеп-аралашып утырыр өчен, берәрсенең өендә җыелу кичәсе; аулак өй. *Егетләрнең күзе төшмиме соң, Егетләрнең күзе төшмиме соң Утырмага килгән кызларга!* Р.Миңнуллин. *Нәҗип абый туздырып чыгарган аулак өйдә безнең белән бергә утырган һәм шул вакытта ук инде минем күңелгә кереп калган Сәкинә исемле кыз кырыгынчы ел башында авылыбыздагы туганнарына утырмага килде.* В.Нуруллин // Шуңа охшатып үткәрелгән кичә. *Кичке утырмада яңгыраган шаян такмаклар, күңелле җырлар, биюләр татар халкының элекке тормышын һәм үткәнен яшь буынга үтемле итеп ачып бирде.* Тәтеш таңнары. *Зур Сәрдектә узган утырмада «Сердәш» фольклор ансамбле катнашты.* Хезмәт даны

**УТЫРМАЛЫ** *с.* 1) Утыртып куела торган. *Михрабның ике ягында берәр утырмалы лампа гына яна, мәчет эче ярымкараңгы иде.* Г.Бәширов. *Халисә, өстәлгә куелган утырмалы көзге каршысына килеп, кат-кат үз-үзен карады.* С.Рафиков

2) *к.* **утырма** III. *Сәләхетдин абзый янына утырмалы якалы өр-яңа зәңгәр сатин күлмәк, чем кара чалбар, башына зерә матур итеп чигелгән түбәтәй кигән Әхмәтзыя чыгып басты.* Г.Галиев

**УТЫРМАЧЫ** *и.* Утырмага килүче, утырмада катнашучы кеше. *Кич утырган яшь кызлар, утырмачы балдызлар! Чүбек бармы, чүбек?!* Ш.Маннур. *Барысын да искә алгач, Шәрифәне яман күздән саклау ниятенә керешеп, янына утырмачы әбине дәштерделәр.* Ф.Яхин

**УТЫРТКЫЧ** *и.* Яшелчә, агач үсентеләре утырту өчен кулланыла торган махсус машина. *Утырткыч белән утырткан очракта, сутыен 20 сумнан санарга кирәк.* Безнең гәҗит. *Үренте утырткыч. Бәрәңге утырткыч*

**УТЫРТМА** *с.* 1) Вертикаль рәвештә эшләнгән. *Чыгырлы иске кое янына баскач, җилкапка, тәбәнәк утыртма читән аркылы хуҗаларның ишегалдына карады.* А.Гыйләҗев. *Тауларга таба байтак вакыт атлагач, урман эчендә биек утыртма койма белән уратып алынган алачыклар күренде.* И.Хуҗин

2) *к.* **утырма** III. *Аннан соң шунысын да әйтергә кирәк: кыршау сыман муенны кысып торган утыртма яка, ялтыр төймәләре тезелеп киткән туры изү, калку күкрәк, тактадай иңбаш – кыскасы, шәп китель аны район җитәкчеләренә, хәтта һәр кабинетта, һәр почмакта урысның иконасы урынына эленеп торган олуг дәрәҗә иясенең портретларына да охшата сыман иде.* Н.Фәттах

**УТЫРТУ** I *ф.* 1) Кемгә дә булса урын тәкъдим итү, утырырга булышу; утырырга мәҗбүр итү. *Танышмы син, юкмы – барып керә-нитә калсаң, хөрмәтләп түргә уздыралар, табынга утырталар, хәленчә сыйлыйлар, хәерле юллар теләп озатып калалар.* М.Хәсәнов. *Әйдәгез, мин сезне яхшырак урынга утыртам.* М.Маликова

2) Яткан, сулган, егылган кемне яки нәрсәне торгызу, вертикаль хәлгә китерү

3) Нәрсәне дә булса вертикаль хәлдә ныгыту, бастырып ясап кую; кая да булса вертикаль хәлдә урнаштыру. *Юлның ике ягына да багана утыртып, капка сыман бернәрсә ясап куйганнар.* А.Алиш. *Никитин проммәйданда тәрәзәгә пыяла кую, ишекләр утырту эшләрендә кешеләрнең артык күп булуын үз күзе белән күрде.* С.Рафиков

4) Кая да булса бару, китү өчен урын алырга, урнашырга ярдәм итү. *Аягыма баса алмаганлыктан, мине, машинага утыртып, медпунктка алып киттеләр.* И.Диндаров. – *Сүз уңаенда шуны да әйтим: бүген синең ата-анаңны, сеңлеңне, поездга утыртып, өйләренә озаттылар, – диде ул, минем күзләремнән атылып чыккан яшьләргә игътибар бирмичә.* И.Хуҗин

5) Үстерү максаты белән, үсемлекнең тамырын, бүлбесен, орлыгын җиргә куму. *Ул җир тимерьюлда эшләүчеләрнеке саналып, алар аны үзара бүлешәләр дә теләгән нәрсәләрен чәчәләр яки утырталар, чи калдырган очракта печәнен чабып алалар икән.* К.Миңлебаев. *Минем бу ярларга өрәңге, имәннәр утыртасым килә.* А.Гыйләҗев

6) Вертолёт, самолёт кебек очкычларны һавадан җиргә төшереп урнаштыру; җиргә төшереп бастыру. *Вертолётны җиргә утыртканда, ул нык итеп бәрелә, һәм койрыгы өзелеп әллә кая оча.* Әлмәт таңнары. *Уфадан Сочига баручы ут капкан самолётны утырткан командирга дәүләт бүләге бирәчәкләр.* Акчарлак

7) Озак башкарыла, үтәлә торган ниндидер эш эшләргә тәкъдим итү яки мәҗбүр итү. *Кәгазь табу, беренче, икенче курс егетләрен күчереп язарга утырту кебек эшләрдә Мирза бик тырышты.* Р.Юныс. *Әнисе тәрәзә пәрдәсен дә үзе бөкләп интекмәгәнне, кызын чигәргә, бәйләргә, тегәргә утырта аламы?* Татарстан яшьләре

8) *сөйл.* Кемне дә булса берәр эшкә билгеләү, кемгәдер нинди дә булса эш йөкләү. *Нинди җаваплы эшкә шундый нәмәрсәне утыртып куйганнар бит.* Г.Гобәй. *Аның урынына зәһәрлектән тәмам кипшергән, акыл сатарга яратучан берәүне китереп утырталар.* К.Миңлебаев // Дәүләт башлыгы, идарәче итеп билгеләү, сайлап кую. *Ә бит күптән түгел генә, шул ук кан коючылар, тантаналы төстә, Олуг Мөхәммәдне Казан тәхетенә утыртканнар иде.* М.Хәбибуллин

9) Нәрсәдән дә булса чикләү; нинди дә булса режим сакларга мәҗбүр итү (мәс., туклануда). *Бәрәңге белән суга утырту. Сөткә утырту*

10) Ирегеннән мәхрүм итеп ябып кую. *Әгәр ул булса, ике дә уйламыйча протокол төзетеп, барыгызны унбиш тәүлеккә утырта идем мин сезне.* А.Хәсәнов. *Әгәр белсәләр, солдатны, ким дигәндә, берничә тәүлеккә карцерга утыртачаклар иде.* Р.Мостафин. *Читлеккә утыртылган кыргый җанвар кебек,*

*үзен чолгап алган әзмәвердәй егетләргә күз салды, кулларын уды, янтавын, кулбашын, аркасын капшады.* Т.Галиуллин

11) Көймә кебек нәрсәләрне нинди дә булса сай, комлык кебек каршылыкка терәп хәрәкәтен туктату, тоткарлау. *Лачын Тауны үткәч, бик ямьсез дәвыл кубып, сал астыннан илле тонна чылбыр сөйрәлеп баруга карамастан, төнлә белән безне сайга утыртты.* Х.Сарьян

12) Берәр нәрсәне аумаслык, таймаслык итеп урнаштыру, ниндидер тигезлек өстенә кую. *Бәрәңгеле кәстрүлен дыңк иттереп идәнгә утыртканнан соң, Алтынбикә капкачны япты.* З.Хөснияр. *Хәлил чәйнекне өстәлгә утыртты да Маликның каршына ук килеп басты.* М.Кәбиров

13) Озаграк саклау өчен яки башка максатлар белән киселгән, өзелгән чәчәк, үлән һ.б.ш. үсемлекләрне, агач ботакларын суга тыгып кую. *Мәгъния, бала көйләгәндәй гөрли-гөрли, вазага су салды, аннары чәчәкләрен берәм-берәм суга утыртты да, читкәрәк китеп, озак кына сокланып карап торды.* Ф.Яруллин. – *Әни, син нигә розаларыңны суга утыртмадың? – дигән тавышка уянып киттем.* Ф.Җамалетдинова

14) Нәрсәне дә булса берәр әйбер очына кидерү, файдаланырлык хәлгә китерү. *Таш балталарны һәм чүкечләрне әүвәлгечә таякка бәйләп беркетү белән генә канәгатьләнмичә, аларны, тишеп, агач сапка утыртканнар.* Р.Фәхретдинов

15) Тайган, каймыккан, чыккан буынны, сөякне үз урынына урнаштыру, кире нормаль хәлгә кайтару. *Ходайның рәхмәте, аның бот сөяген икенче көнне үк урынына утыртканнар.* Р.Гыйлемханов. *Буынны утырткач, акрынлап аякка баса, башка яралары да төзәлә.* Кызыл таң

16) Нәрсәне дә булса суыту яки җылыту максаты белән, шул әйбер салынган савытны, салкын яки кайнар су тутырылган тагын да зуррак савытка урнаштыру. *Миндаль яисә көнҗет мае салынган шешәне кайнар суга утыртып җылытыгыз.* Сөембикә. *Майны чишмә суында басып, 400 әр грамм итеп йомарлап, чиләкне кичтән салкын суга утырттым.* Өмет

17) Ашамлык, эчемлекне өстәл өстенә китереп кую. *Галимә ашны табак белән өстәлгә китереп утыртa.* А.Алиш. *Шуның өстенә тагын, әнисе чәй яңартып, чәй утырткач, Сәйфинең теле отыры озынаеп китте дә Миңнулланың җен ачуларын чыгарды.* В.Нуруллин

18) Су, чәй кайнату, аш һ.б. ризыклар пешерү максаты белән чәйнек, кәстрүл кебек савытларны плитәгә куеп, кабызып җибәрү; кайната, пешерә башлау. *Кичке эңгер-меңгер төшә башлауга ук, аш утыртты, Убыр чишмәсеннән сулар ташый-ташый, мунчасын да якты.* В.Имамов. – *Чүлмәк белән аш утырттым, хәзер пешеп чыга, – диде аңа тагын да Җабир сахабә.* Ф.Яхин

19) Яка, җиң һ.б.ш. кебекләрне урынына тегеп беркетү. *Берсенең җиңен кыек утыртканнар, икенчесенең якасын.* Ф.Яруллин. *Ә бүген кызлар күлмәгенә яка утырту операциясе тәки харап итте Фәрданәне.* А.Вергазов

20) Бер предметны икенчесенә беркетү; нәрсәгәдер кигезеп, ябыштырып, беркетеп кую. *Аның исемен калай кисәгенә язып, шуны торбага эретеп ябыштырып утыртканнар.* Ә.Гаффар. *Хәтта иң очына янып торган кызыл йолдыз да утыртканнар.* Ф.Яхин

21) Чеби, бәпкә чыгарсыннар өчен, тавык, каз, үрдәк кебек йорт кошларын оядагы йомыркалар өстенә урнаштыру. *Быел тавык утыртмадым.* Н.Фәттах. *Каз бәпкәләре йөртергә урын кирәк, каз утырттым быел.* Н.Кәримова

22) Кертү, тидерү, тыгу, кадау (атыла торган нәрсә тур.). *Түләү турында сүз дә булу мөмкин түгел, авыз ачсаң, кем булуыңа карамастан, маңгайга пуля утырту белән генә яныйлар.* Ф.Сафин. *Исән калу шарты шундый, юкса аркага пуля утыртачаклар.* З.Мәхмүди

23) *күч.* Китереп бәрү, ору, нык итеп сугу; ману, кундыру, салу. *Матрос киемле тиз генә бер кулын ычкындырды да надзирательнең кабыргасына шундый ипле итеп утыртты.* Г.Гобәй. *Ләкин беркөнне, читләтеп кенә булса да, Франциядәге «азат тормыш»ны мактап сөйли башлагач, тоткыннарның берсе, ни өчен икәнен әйтеп тә тормастан, Поцелуйкинның борын төбенә шундый итеп утыртты, Поцелуйкинның күзләре шакмак булды.* Г.Әпсәләмов

24) *күч.* Алдау. *Бик нык утыртканнар аны Чистай базарындагы барышниклар. Тик ул ничек алданганын һичкемгә сөйләми ---.* Ш.Маннур. *Утырткан ул үзеңне. Рәхмәте шул булсын.* К.Миңлебаев

◊ **Утыртып китү** Алдау. *Юртакка килгән кеше Габдрахман байны да, мине дә утыртып китте.* Х.Хәйруллин

**Утырта бару** Акрынлап, эзлекле рәвештә утырту. *Умарталарны машиналардан бушатканда ук, ояларны иплӛп кенә утырта барыр өчен, казыклар кагып чыктылар.* А.Хәсәнов. *Ала баралар, коридорга чыгарып утырта баралар.* З.Зәйнуллин

**Утырта башлау** Утыртырга тотыну. *Атау урамы халкы бәрәңгеләрен утырта башлаган икән.* В.Гали. *Ул арада пассажирларны очкычка утырта башладылар.* М.Әмирханов

**Утырта тору** Ниндидер эш эшләнгәнче утырту; һаман утырту. *Мин кайтканчы, энем, алмагачлар Утырта тор безнең нигезгә!* Р.Миңнуллин. – *Әтиегез сугышта, сезне нәрсә ашатып туйдырырмын? – дип, аның утырткан агачларын йолкып ташлаган саен, нәни Самат туктаусыз яңаларын утырта торды.* Р.Гариф

**Утырта төшү** Беркадәр утырту. *Яткан җиреннән утырта төшү*

**Утыртып алу** Тиз арада утырту; аз вакытка утырту, беразга утырту. *Әйдә, кызым, без әле генә эчкәниек менә, чәй суынмаган да, суынган булса, тагын газга утыртып алырбыз, син чәй эчеп ал әле, юлдан килеп, тамагың ачкандыр.* З.Хөснияр

**Утыртып бару** Өзлексез, бер-бер артлы утырту. *Әтиләре аларны рәтрәт итеп утыртып бара, әниләре аңа ярдәм итә, Фәрит кечкенә чиләк белән кәбестә утыртасы чокырларга су сибә.* Н.Каштанов

**Утыртып бетерү** Булган берсен утырту; барысын да утырту; тулысынча утырту; утыртуны төгәлләү. *Атасы, бөтен кеше бәрәңге утыртып бетерде, безнең бакча да сөрелмәгән.* Ф.Яруллин. *Үзләрен генә түгел, гаиләләрен, туганнарын, дус-ишләрен, таныш-белешләрен утыртып бетерәләр.* Р.Мостафин

**Утыртып җиткерү** Тиешле дәрәҗәдә, кирәк кадәренчә утырту. – *Ул бик галим кеше, ул бөтен нәрсәләрне тикшереп бара, – дип җавап бирүе дә хатынын бер тиенлек тә үз тупсасына утыртып җиткермәгән иде.* Г.Толымбай

**Утыртып кую** Тиз арада яки көтмәгәндә утырту; алдан утыртылган хәлгә китерү. *Шуны гына көткән Әлфред, кинәт кенә әллә нинди хикмәтле бер хәрәкәт ясап, ботны урынына утыр-*

*тып куйды.* Ф.Яруллин. *Анда алгы бүлмә, аш бүлмәсе ясады, эченә җылыту казаны урнаштырып, пөхтә генә мич утыртып куйды.* Я.Шәфыйков

**Утыртып тору** Гел, даимән утырту; әледән-әле утырту; билгеле бер вакыт дәвамында утырту; хәзерге вакытта утырту. *Гомер бакый шулай инде: утыртып торасың, череп торалар.* З.Мурсиев. *Мин колхозчыларның кенәгәләренә хезмәт көннәрен утыртып торганда, бик батыр кыяфәт белән идарәгә килеп керде бу.* В.Нуруллин. *Мәснәви әле иректә иде, аны унбиш тәүлек утыртып тордылар да чыгардылар.* Н.Акмал

**Утыртып чыгу** Барысын да, һәрберсен утырту. *Сукрана-сукрана, умарталарны яңадән казыкларга утыртып чыктым.* А.Хәсәнов

**УТЫРТУ** II *и.* 1) Утырту (I) эше, гамәле. *Язын – чәчү, утырту, җәен – карап үстерү, печән әзерләү, көзен – урып-җыю һәм, шушылар белән беррәттән, ел әйләнәсе мал-туар карау.* С.Арсланова

2) Кая да булса китү алдыннан, урнашу, урын алу өчен, вагонга, пароходка, очкычка кертү эше. *Ул арада самолётка утырту башланды.* А.Хәсәнов. *Сәгать тугызда китәчәк «Яр Чаллы – Зәй» автобусына алтынчы платформада утырту башлана.* З.Хәким

**УТЫРУ** *ф.* **1.** 1) Аяк өсте басып торган яки яткан хәлдән аякларны сузып, салындырып яки бөкләп, арт белән урындыкка, идәнгә һ.б. тиеп урнашу. *Разия, ут кабызмый гына, караватына барып утырды...* А.Алиш. *Йокы төшәсе юк иде, шуны аңлап, карчык тагын торып утырды.* А.Әхмәтгалиева

2) Шундый торышта булу. *Галимҗан абый баш өстенә җәймә корган, талчыбыктан үргән кәнәфидә утыра.* А.Хәсәнов. *Хөршидәттәй ялгыз түгел, олы якта самавыр янында бер ят әби дә утыра.* А.Тимергалин

3) Кая да булса бару өчен берәр транспорт чарасына урнашу, шуннан урын алу. *Ул үзенең, бар дөньяга кул селтәп, беренче очраган поездга утырып китүенә сөенеп бетә алмады.* Р.Вәлиев. *Бер үк машинага утырып кайттылар.* Г.Гыйльманов

4) *сөйл.* Нинди дә булса эштә булу, шул эшкә ныклап урнашу һәм озак эшләү. *Беләсең: кайчандыр монда, идарә башында, нефтьчеләрнең иң зур җитәкчесе булып, минем төпчек улым утыра иде.* А.Гыйләҗев. *Картлар әйтмешли, күбесе Татарстаныбызның олы шәһәрләрендә зур урыннарда утыралар икән.* Н.Гариф

5) Нинди дә булса урында озакка яшәргә калу; төпләнү. *Бәхәссез, бу сүзләрдә дә Батый хан үзе генә белгән тирән мәгънә ята: яубаш Атилла бабасы нигезләгән калада утырып калу турында да уйлаган.* М.Хәбибуллин

6) Билгеле урында, рәвештә, максатта вакыт үткәрү; кайдадыр булу. *Тукта, без бит концертта утырабыз лабаса!..* Ә.Еники. *Биш минуттан ул кичерәк кенә тамаша залында икенче рәттә утыра иде инде.* А.Тимергалин

7) Кайда да булса даими рәвештә яки озак вакытлар булу, беркая да чыкмый тору. *Заһидлар төсле өйдә утырып торырга кирәкмени?* Г.Исхакый. *– Өйдә булмыйча кайда булсын? – диде Фатихәттәй, Мансурның өйдә утыруын яратмавын ап-ачык сиздертеп.* Г.Әпсәләмов

8) Билгеле бер урынга урнашу, билгеле бер җирдә төзелү. *Гомәр дәвалана торган санаторий урнашкан Алып каласы Ай-Петри кыясы белән Кара диңгез арасына утырган.* Г.Рәхим. *Сазлык, су өстендә утыра бу авыл.* Кызыл таң

9) Тоткынлыкта булу; ирегеннән мәхрүм ителгән, ябылган булу. *Өч ел утырып чыкты, әмма акыл кермәде үзенә.* Г.Гыйльманов. *Кияү, Фәниснең төрмәгә утырганын белеп, хатын ягындагылардан тагын да ераграк торуны кулайрак күрде булса кирәк.* Д.Гыйсметдин

10) Хәрәкәт итүдән, очудан туктап, бер урынга куну, шунда хәрәкәтсез тору (кошлар, бөҗәкләр тур.). *Ә анда, мүк өстендә, гаҗәеп бер күбәләк утыра иде.* Р.Фәизов. *Ябалдашы киселгән тупылда ала карга утыра.* Р.Рахман

11) Җиргә яки башка берәр нинди өслеккә төшү; хәрәкәт итүен туктату (оча торган техника, парашют һ.б. тур.). *Шул тирәдә эшләүчеләр, «бу ни хәл» дип, самолёт утырган җиргә йөгерәләр.* М.Әхмәтҗанов. *Вертолётлар утыра торган мәйдан – җил оясы.* Ялкын

12) Кая да булса төшү, куну; берәр нәрсәнең өстенә яки төбенә җыелу (һавада очып йөргән нәрсәләр яки сыеклыктагы кисәкчекләр тур.). *Ләкин тора-бара аның суы саеккан, чүпләнеп, төбенә ләм утырып һәм ярлары ишелеп, агудан бөтенләй диярлек туктаган, аннары ярның сөзәк урыннарына җәелеп, үтеп чыккысыз бер сазлык хасил иткән.* М.Галәү. *Өстәл өсләренә, сыннарга калын катлам булып тузан утырган.* Н.Акмал

13) Нәрсә дә булса килеп терәлү, кадалу, тыгылу. *Тамакка балның ачысы утыру* // Шуңа охшаш хис барлыкка килү. *Куркыныч уйдан Әлифәнең сулышы киселде, тамагына ачы төер утыргандай булды.* М.Маликова

14) Кая да булса нык яки тирәнгә кереп урнашу. *Карынчыкта зур пуля утыргач, йөрәк бөтәнчәрәк типкәндер.* Х.Камалов

15) Җиргә, суга бату, сеңү, иңү. *Өч кат йорт биеклеге салгач, [завод] стенасы утырды.* С.Рафиков. *Аннары инде нигезгә яңадан балчык ташыйлар, йорт утырмасын өчен, балчыкны кире үз урынына төеп тутыралар.* М.Зарипов

16) Нинди дә булса тоткарлыкка очрап, төртелеп туктау, алга бара алмау. *Дүрт кеше менгәч, көймә сайга утырды, ләкин, тирәнгәрәк керткәч, әле аның тагын ике малайны рәхәтләнеп күтәрә алуы беленде.* А.Тимергалин

17) Басылу, тыгызлану (көпшәк матдәләр тур.). *Шулай да бер вакытны ямьле яз ишек кага: кар утыра, челтәрләнә, ачыла башлый, без, малай-шалай, ирекккә ыргылабыз, кар сулары агыза башлыйбыз, аннары куйларны (бездә нигәдер сарык димиләр, күбрәк куй дип сөйлиләр) инеш аръягындагы чалуга, ягъни болынга алып чыгабыз; бу вакытта инде терлек азыгы такытокы гына калган була.* Г.Әпсәләмов

18) Юешләнүдән, дымланудан кыскару, тараю, кечерәю. *Чуар күлмәк [кызның] гәүдәсен зифа күрсәтсә дә, бераз утыра төшкән иде бугай.* С.Рафиков. *Йон әйберләрне саклык белән юарга кирәк, аларны ышкырга, борырга бик ярамый, утырырга мөмкиннәр.* Сөембикә

19) Гәүдәгә, өскә берәр форма, кыяфәт биреп тору (кием тур.). *Гаскәри кием аның өстендә ят утыра.* Ш.Усманов. *Кием өстә ямьсез утыру*

20) Үсешнең билгеле бер стадиясендә булу, хәлдә булу (үсә торган үсемлекләр, агачлар тур.). *Борчак – орлыгын гына кайтарган, карабодайны инде анысын әйтәсе дә юк: чәчәктә утырганда ук эссе куырган.* Г.Бәширов. *Җил йөри шаярып-шатланып, Бөредә утыра имәннәр.* Д.Сирай

21) Үзеңне нәрсәдән дә булса чикләү; билгеле бер режим, рацион сакларга мәҗбүр булу. *Хезмәттәшем һәм фикердәшем, үзендә диабет чире чаткылары сизелүгә, катгый диетага утырды.* Т.Нәҗмиев. *Икенчедән, Алмотыга кайтып җиткәч, ике көн җиләк диетасында утырып, җимеш күрмәс хәлгә җиттек.* Р.Гыйлемханов // Ябыгырга теләп яки башка сәбәп аркасында бер төрле азык белән генә туклану. *Күпләр көннәр буе төрле сайтларда ябыгу рецептлары эзләп, коры суда, кефирда утыра яки, тәүлек буена бер алманы кимереп, бер генә размер булса да кечерәк кием кию турында хыяллана.* Өмет. *Бабай кайткач карчыгына сөйли, врач сөттә генә утырырга кушты, ди.* Заман сулышы

22) Формалашып бетү; ныгу; даимигә әйләнү (холык, дөньяга караш һ.б.ш. тур.). *[Гәүһәр] тормышта күбрәк күргән, холкы да утыра төшкән.* Г.Әпсәләмов. *Ул киткәндә, ике яшьтәге хәтер утырмаган бала булганмын, ә инде ул кайтып кергәндә – мәктәпкә керү дәрте белән йөрүче малай идем...* Ф.Баттал

23) Тынычлану, басылу, элекке халәтенә кайту (күңел, ярсулы хисләр тур.). *Ул, яшь күңел бер җилкенер дә утырыр, дип уйлаган иде.* Г.Ибраһимов. *Яшь вакытында адәм баласы талымсыз, чөнки әле аның акылы әйле-шәйле. Хисләре утырмаган, кайнар ташкын кебек, тән тиресе эчендә ургыла-ургыла ага.* Х.Камалов

24) Озак явымнардан соң көннәр яхшыру, һавалар әйбәтләнү, көннәр аязу. *Көннәр утырып китеп печән мәшәкатьләрен җиңеләйтүгә, уку башланганчы, барлык материалларны белән берәр бура алып мунчаны яңарту теләге көчле егеттә.* А.Хәйретдинова

25) Билгеле бер вакытта бала чыгару өчен, йомырка өстендә булу (кошлар тур.). *Машаның бәхетеннән, йомыркалар барысы да яраклы булып, әнә кара тавык утыра торгач, һәркайсыннан берәр бәпкә дә дөньяга борынлап чыкты.* Ә.Еники. *Өйдә сикерергә ярамый – каз утыра.* Ә.Дусайлы

26) Эчкә батып, нурсызланып калу (күзләр тур.). *– Көннән-көн ябыкты, буыла-буыла ютәлли башлады, күзләре генә утырып калды, – дип сөйләде Азат.* А.Тимергалин. *Ябыгып, күзләре утырып, йөзе саргаеп калган әниләреннән тәүдә ятсынып, кырын-кырын карап торган балалар бераздан инде шау-гөр килешә башладылар.* Д.Булатова

27) Уку программасын үзләштерә алмау сәбәпле, югарырак сыйныфка күчмичә, кабат шул ук сыйныфта укырга калу. *Ике ел бер класста утыра инде ул.* Ф.Яруллин. *Хәмит үзе инде икенче елын бишенче класста утыра, исәп-хисапка мондый маһирларны җене сөйми иде.* Р.Фәизов

28) Кияүгә чыкмый калу; озак кияүгә чыкмый тору. *Менә, Ходай боерса, һич көтмәгән җирләрдән менә дигән бай улларыннан яучылар килер әле. Утырган кыз безнеке генә түгел.* Г.Камал. *Яучы килә дә китә, Фатиха һаман бармый, һаман утыра бирә.* Г.Ибраһимов

29) *күч.* Берәр мәсьәләдә алдану. *Утырдым, җизни, бик нык утырдым.* Т.Гыйззәт

30) *күч.* Егәре бетү, көчен әкренләп югалту (аккумулятор, батарея һ.б. тур.). *Шайтан алгыры, аккумуляторы утырган [машинаның]. Аккумуляторы утырмаган булса, йөртеп карарга да була иде.* М.Юныс

31) *күч.* Элекке көче, егәре бетү; сафлыгы кимү (тавыш тур.). *Ләкин аның тавышы элекке кебек саф, нечкә түгел, бераз утырган ---.* Р.Батулла. *«Фонограмма зыянлымы» дигән сорауга җавабым мондый: гел «авыз ачып» кына «җырлап» йөрсәң, тавыш утыра, диапазон кечерәя, тавышның көче кимегәннән-кими бара.* К.Сатиев

32) *күч.* Мәгълүмат эзләү, нәрсә дә булса уку, тыңлау, карау, уйнау өчен интернеттан файдалану; шунда күп вакыт үткәрү. *Алай гына да түгел, көнозын тырай тибүләр, интернетта утыручылар да күпмегәдер онытылды.* А.Гыймадиев. *Инстаграмда утыручылар арасында үз битләрендә бер фото да куймыйча, укып-карап кына ятучылар да бик күп.* Безнең мирас

33) *күч.* Күк җисемнәре офык артына төшеп күмелү; баю, бату. *Халык эштән кайткан, кояш утырыргамы, юкмы икәнлеген чамалаган вакытлар иде.* Ф.Яхин

**2.** *ярд. ф. функ.* Төп фигыльдә аталган эш-гамәл, хәл һ.б.ш.ның дәвамлы булуын белдерә. *Үзе белән сөйләшмәсәләр дә, шуларга карап юанып утыра иде Ханәфи.* В.Нуруллин. *Боларның дөнья бетереп уйнап йөргәннәрен бер мәче күреп алган да почмак буйлап үрмәләп түбәгә менгән, аннары, морҗа артына посып, күзәтеп утыра башлаган.* Ф.Яруллин

◊ **Утырып калу** 1) Алга китүдән, үсүдән туктау. *Тыйнак булсаң, гомергә шушы тулай торакта утырып калуың бар дип, юмартланып, егетләргә кочагын ачты.* Ф.Яруллин. *Болай бит син гомерең буе цехта утырып калачаксың.* Р.Батулла; 2) Нәрсәдән дә булса мәхрүм калу, эләкмәү. *Алданып Хуҗа чокыр төбендә буш утырып калгач кына белеп ала.* Ф.Яхин; 3) Башкалар китеп бетеп, үзе генә яки үзләре генә калу; башка мөмкинлек булмаганлыктан һаман шунда яшәргә мәҗбүр булу. *Айнур өйләнеп башка чыкса, Камил белән икәү генә утырып калабыз инде.* Н.Гаетбай. *Төп нигездә биана белән Әмдәзия утырып калды.* Н.Көбәш; 4) Шулар гына торып калу; аерылып, күзгә бәрелеп торырлык дәрәҗәдә аз калу. *Җимерек өйләр, шап-шәрә утырып калган мичләр, көл һәм кисәү мәйданнары шуны күрсәтәләр.* Г.Кутуй. *Тирә-якта барлык каралты-кура күмергә әйләнгәндә, таш мәчет берүзе утырып калган...* Н.Фәттах

**Утыра бару** Акрынлап утыру; торган саен күбрәк утыру. *Ләкин моны ишетү барыбер күңелсез, алар кечкенә Фәнзиянең күңеленә юшкын булып утыра бардылар.* Ә.Сафиуллин. *Йөрәгенә туң утыра барып, аны эретерлек һичкем табылмас төсле иде.* Ф.Яхин

**Утыра башлау** Утырырга тотыну. *Тузан утыра башлау*

**Утыра бирү** Бернигә дә карамыйча утыру; һаман утыру; утыруын дәвам итү. *Разил ике бармак арасыннан гына төшереп җибәрде дә берни булмагандай утыра бирә.* Р.Юныс. *Ир һаман башын әле уңга, әле сулга боргалап утыра бирә...* Ф.Җамалетдинова

**Утыра тору** Берәр эш-хәл башланганчы, кемнедер көтмичә утыру; әкренләп, аз-азлап, эзлекле рәвештә утыру. *Сез, әти, утыра торыңыз әле, чәй эчеңез, мин мәктәп эше белән тизгә генә барып киләсем бар.* Г.Исхакый. *Мин хәзер кайтам. Сез утыра торыгыз...* Г.Кутуй

**Утыра төшү** Беркадәр утыру; тагын да ныграк утыру. *Җыры беткәндә, йөрәге бераз урынына утыра төшкән Сабирәттәй инеш буасы янында басып тора иде.* Ә.Хәсәнов

**Утырып бетү** Тулысынча утыру; барысы да утыру. *Кортларның уты-*

*рып беткәннәрен күтеп, оя авызларын юеш чүпрәкләр белән томалап чыкканчы, төнге унберләр дә җиткәндер.* А.Хәсәнов. *Утырасы кеше утырып беткәч, өстәлгә учакта кыздырып пешерелгән куй чыгарып салдылар.* М.Әмирханов

**Утырып җитү** Тиешенчә утыру; тәмам утыру. – *Фатыйма апай, – диде ул, әле утырып җитмәгән яшүсмер тавышы белән.* Р.Мөхәммәдиев. *Белмим, кызым, күңелем һаман утырып җитә алмый.* Г.Гыйльманов

**Утырып калу** Нинди дә булса сәбәптән соң утыру; утырган хәлгә килү; күпмедер вакыт кына утыру; күпмедер утырырга өлгерү. *Барысы да ачы юшкын булып һаман бер йөрәккә утырып кала бирә – ана йөрәгенә.* А.Гыйләҗев. *Әмма бу юлы ул Казан тәхетендә нибары дүрт ай гына утырып кала – Сафагәрәй хан кайтып, аны Казаннан куып чыгара.* Ф.Бәйрәмова

**Утырып карау** Сынап карау өчен утыру. *Их, Мәҗит исән чакта менә шундый машиналарга утырып карый алмады.* Ф.Яруллин. *Руль артына да утырып карыйсы килә бит ул.* Ф.Яхин

**Утырып китү** Берәр нәрсә тәэсирендә утыру. *Юк, Газизә, мин үсмәдем, костюм утырып киткән.* А.Гыйләҗев

**Утырып кую** Тиз генә утыру. *Хәят дигәннәре шушы көйгә акса, бу әмирнең Сәлим хан урынына да утырып куюы бар.* В.Имамов. *Яшел чапан, бохарча уралган чалма киеп, идәнгә утырып куйган.* Шәһри Казан

**Утырып тору** Даими, озак вакыт дәвамында утыру; әле, хәзер, сөйләү моментында утыру; утырган хәлдә булу. *Беркөн иртән уянсам, әбием ятагында утырып тора, мин уянганны күрүгә, юрганы белән капланды.* Р.Батулла. *Баксаң, ул зур гына пыяла бинада, затлы кызыл кәнәфидә утырып тора икән.* З.Мәхмүди

**Утырып чыгу** Билгеле бер вакытның башыннан ахырына кадәр утыру. *Ул төндә Гайнелвафа карчык та Гөлчирә караваты янында утырып чыкты.* М.Мәһдиев

**УТЫРЫМ** *и. к.* **утырма** I (*1 мәгъ.*). *Утырым барлыкка килгәч, эремә туендырылган була.* Яшь натуралистларга. *Әмма боз эретеп ясалганда, минераль компонентлар юкка чыга, алар утырым хасил итәләр.* Безнең гәҗит

**УТЫРЫП** *рәв.* Өзлексез, тоташ (гадәттә көзге вак яңгыр явуы тур.). *Ләкин яңгыр утырып яумады, бераздан туктады.* Р.Кәрами. *Юл пычрак, баткак. Атнага якын утырып яугач ни!* Д.Булатова

**УТЫРЫШ** *и.* 1) Утыру хәле; утыру рәвеше. *Кыз утырышын үзгәртми һәм сүзгә кушылмый гына тыңлый иде.* А.Шамов. *Дәрес вакытында, кеше күрми әле дип, берәр кыз бик бирелеп борын чистартамы, мәктәпкә килеп тырнак астын тикшереп утырамы, урындыкка утырыш рәвешләре – барысы да сизгер, усал, күзәтүчән Альберт күзе аша уза һәм үтергеч бәя ала.* Р.Батулла

2) Нинди дә булса оешма, коллектив әгъзаларының берәр мәсьәләне карау, хәл итү өчен үткәрелә торган кыска җыелышы, киңәшмә. *Керү белән Җәмилне Кадыйров түр кабинетка – утырышлар уза торган якка алып кереп китте.* Н.Әхмәдиев. *Утырыш барганда исә авызыма су кабам – әйтерсең бер катышым да юк...* Р.Юныс

**УТЫРЫШУ** *ф. урт. юн. к.* **утыру**. *Әйбәтләп утырышкач, Гамил, чалбар кесәсеннән ике пәрәмәч чыгарып, Өлфәткә тоттырды.* А.Тимергалин. *Алданрак килгәннәр эскәмияләргә утырышты, соңга калганнар идәнгә тезелеште.* А.Әхмәтгалиева

**Утырыша башлау** Утырышырга тотыну. *Озак та үтми, кунак өйнең ишек төбенә кыңгыраулы атлар килеп туктады, һәм кодалар, чыгып, шуларга утырыша башладылар.* Ә.Еники. *Өстәл янына утырыша башлаганда гына, ишек кыңгыравы зеңгелди.* З.Хәким

**Утырыша тору** Алдан, ниндидер эш эшләнгәнче, шуның белән бер вакытта утырышу. *Ләкин Риза Рәҗәпов кабинетыннан чыгуга ук: – Сез утырыша торыгыз, мин хәзер кайтам, – дип, күздән югалды.* Г.Кутуй

**Утырышып алу** Тиз генә утырышу. *Табынга утырышып алгач, Шәмсүн алтын йөгертелгән бәллүр рюмкаларга әрмән коньягы агызды да сүз башлады: «Бүгенге мәҗлесебез минем сабакташ дустым Рәфиснең совхозыбызга урнашып эшли башлавы уңае белән оештырыла».* А.Вергазов

**Утырышып бетү** Барысы да утырышу. *Утырышып беткәч, машина алга ыргылды, гүя ул тизрәк тормыш кайнаган җиргә – кешеләр арасына омтыла иде.* Ә.Сафиуллин. *Без утырышып бетү белән, теге чибәр хатын кереп, Президент колагына нәрсәдер пышылдады.* З.Зәйнуллин

**Утырышып тору** Даими, әледәнәле утырышу; әле, хәзерге вакытта утырышу. *Аның уң ягында Гайшә, сул ягында Әминә җиңел кисияләргә төренеп утырышып торалар.* К.Тинчурин

**УТЫРЫШЧЫ** *и. махс.* 1) 1917 елга кадәрге Россиядә нинди дә булса дәүләт яки суд учреждениеләре эшен тикшерүдә катнашучы. *Утырышчы булуы белән горурлануы аның йөзенә үк чыккан иде.* М.Галәү. *Утырышчы вазифасы йөкләнде*

2) Совет чорында халык судында карала торган эшләрне тикшерүдә катнашу өчен хезмәт ияләре арасыннан сайланып куелган вәкил; *русчасы:* **заседатель**. *Юллар мине бүген суд залына утырышчы итеп китерде.* И.Юзеев. *Шуңа да тыныч тормышта ул, төп хезмәтеннән тыш, җәмәгать эшләрендә катнашкан, халык судында утырышчы вазифаларын да башкарган.* Туган як // Суд эшенә катнашу өчен сайлап куелган кешеләрнең берсе. *Нигә унике кеше дигәндә, аларда присяжныйлар суды бар, анда унике утырышчы.* Р.Кәрами

**УУ** *ф.* 1) Нәрсәне дә булса кул белән ышку, басып, кат-кат сыпыру. *Малай өметсезләнеп ишеккә карый, нәни йодрыкларын йомарлап, күз тирәләрен уа.* А.Гыйләҗев. *Ике кеше бергә егылса да, һәркайсы үз шешен уа.* В.Имамов

2) Берәр нәрсәне үз-үзенә ышку. *Председатель әйтеп куйды, Учларын уа-уа: – Кыска тотыгыз, егетләр, Соңыннан банкет була.* Г.Афзал. *Ул, кулларын уа-уа, дәртләнеп үк йөри башлады.* В.Имамов

3) Тәнгә нәрсә дә булса ягу, сылау, ышку (массаж ясаганда һ.б.ш.). *Аңа, Галиуллага, хәзер спирт бирделәр, ә ул аның белән аягын уа...* А.Алиш. *Элек аякларын карады, ниндидер төнәтмә белән уды, аннары кара чүпрәк белән бәйләгән күзен ачтырды.* М.Хәбибуллин

4) *сөйл.* Кат-кат ышку, сыпыргалау, массаж ясау. *Әллә бу карт әнинең аркасын уарга мунчага кереп чыгар?* М.Мәһдиев. *Арканы уарсың, миллек белән чабарсың, өстеңне сал, давай.* В.Имамов

5) Кер юу. *Яше туксанда булса да, киленнәргә бер мәшәкате дә тими: үз пычрагын үзе җыеп, үз керен үзе уа.* Г.Әдһәмова. *Вакыты булган саен кер уды.* Ф.Җамалетдинова

6) Йомшарту, каткан кердән чистарту өчен, берәр нәрсәне үз-үзенә ышку.

*Чалбар балакларын уу. Курткасындагы балчыкны уу. Кәгазь уу*

7) Берәр нәрсәне изеп, укмаштырып, төерләр, кисәкләр барлыкка китерү. *Соңгы уч оннан боламык уып ашалды...* Г.Гыйльманов

8) Угычта кырып, төеп һ.б. рәвешле ваклау, порошок яки таралучан масса хәленә китерү. *Аннары без икәүләп Барсаның аякларын юып, җәрәхәтләренә киптерелгән бака яфрагын уып сиптек тә йомшак чүпрәк белән кысып бәйләп куйдык.* Г.Галиева

**Уа башлау** Уарга тотыну. – *Юньләп аңлатыгыз ла! – диде Альберт һәм, мәзәк күрәчәгенә куангандай, кулларын уа башлады.* А.Тимергалин

**Уа бирү** Ууын дәвам итү. *Кирегә юл юклыгын хатын яхшы аңлый, шуңа, апасы авылга кайткан төмсә көнне каһәрли-каһәрли, һаман кер уа бирде...* Ф.Җамалетдинова

**Уа тору** Берәр эш-хәлгә кадәр уу; өзлексез уу. *Эшең булмаса, тун итәгеңне булса да уа тор, дигәндәй, алъяпкычына бөрелгән балаитәкләрнең әле бер, әле икенче почмагын бөтәрләде дә бөтәрләде Тәслимә.* Р.Рахман

**Уа төшү** Бераз уу; тагын да ныграк уу. *Байтак уа төшкәч, Зөмәрә татлы мышнап черем итеп китте.* Х.Камалов

**Уып алу** Тиз генә уу. *Ногайбәк ага учын учка уып алды.* А.Хәсәнов. *Үзен тынычландыру өчен, гадәтенчә, сул кулы белән күзләрен уып алды.* Т.Галиуллин

**Уып җибәрү** Кинәт, искәрмәстән уу; бераз, беркадәр уу. *Җәт-җәт барган көйгә уч төбеңә җылы сулыш өреп аласың да, кызлар күрмәгәндә, колакларыңны уып җибәрәсең – берни түгел, туңу кая инде ул, ут булып кызыша башлыйлар әле хәтта.* Р.Мөхәммәдиев. *Бәрәңгене пешерергә куйганнан соң, иттарткычтан чыгарылган итне суган, тоз, борыч белән болгатып (кайчагында берәр кишер дә уып җибәрәм), майлы табада кыздырам.* Ватаным Татарстан

**Уып кую** Алдан яки тиз арада уу. *Ул чыгып киткәч кенә, полковник, нәрсәнедер исенә төшергәндәй, маңгаен уып куйды.* М.Маликова. *Ул, үз уйларыннан үзе ләззәтләнеп, тәне кымырҗып, тез башларын уып куйды.* Э.Шәрифуллина

**Уып ташлау** Тиз арада уу. *Әмма аның шөпшә кебек нечкә билле, чандыр гына, сөяктән генә төргән хатыны бар, ире берәр көнне салып-нитеп кайтса, әлеге чандыр хатын тегене умач итеп уып ташлый ---.* М.Мәһдиев

**Уып тору** Әледән-әле яки өзлексез уу; әле, хәзерге вакытта уу. *Башта тәмләп киерелеп, аннары ике күзен уып торганнан соң, мине күреп алды.* А.Хәсәнов

**УФ** *ы.* 1) Ару-талу, сызлану, әрнү, газаплану, кайгыру, эч пошу, борчу, үкенү, зар хисләрен белдерә. *Уф, баш авырта башлады.* Г.Афзал. *Уф, арыдым мин, ары бер адым атларлык та хәлем юк...* Г.Гыйльманов. *Уф, табаны салкын су белән юасы була инде – менә монысы бер дә күңелле эш түгел.* А.Әхмәтгалиева

2) Курку, кот очу, шомлану, шикләнүне белдерә. *Уф, котымны алды.* З.Хәким. – *Уф, куркыттың, – диде ул, битен сыпырып.* И.Диндаров

3) Берәр авыр эштән, хәвефле вакыйгадан соң җиңеләеп, тынычланып калуны белдерә. *«Уф, котылдым бугай, эздән яздырдым кабахәтләрне», – дип, иркен сулап куйды Нурулла.* Г.Әпсәләмов. *Уф, ярый әле төш кенә икән, дип сөенеп уянам...* М.Вәлиев

◊ **Уф алла арбасы** Әйбер ташу өчен кулланыла торган бәләкәй арба, кул арбасы. *Исмәгыйль исә көн дә бурлак кебек уф алла арбасы белән якын-тирәдәге йортлардан калдык азык-төлек җыеп йөри.* З.Мәхмүди. *Шуңа да малай икмәк арасыннан зәңгәр чәчәк үләне җыюның, уф алла арбасы белән печән ташуның, кием-салымга, төрле әйберләргә кытлыкның ни икәнен белми дә, аңламый да.* Ә.Закирҗанов

**УФЛА́У** *ф. к.* **уфылдау**. *Кабан күле буенда Апанаевлар мәдрәсәсенә «Приют» дип язылган язуны күрде, тагы бер уфлады да хәзерге Екатеринский урамга чыга башлады ---.* Г.Исхакый. *Ник уфлыйсыз? Миңа бит белергә кирәк. Кайчаннан авырый әле?* Сөембикә

**Уфлап алу** Берара, бераз уфлау. *Вакыт-вакыт уфлап ала да тагын эшенә керешә*

**Уфлап йөрү** Әледән-әле, даими уфлау. *Уфлап йөрүчеләр күп булыр, барысын да тыңлый башласаң...* Кызыл таң

**Уфлап кую** Бер тапкыр уфлау. *Зәйни, ертык гармун шикелле, озын гына бер уфлап куйды, әмма кайтарып сүз әйтмәде.* Ә.Еники. *Бәндәләргә төшкән шул афәттән Бер чайкалып уфлап куясың.* Н.Нәҗми

**Уфлап тору** Һәрвакыт уфлау; хәзер, шушы вакытта уфлау. *Уфлап тормагыз әле! Баш катырмагыз әле!* Л.Лерон

**Уфлый башлау** Уфларга тотыну. *Әби тагын уфлый башлады инде*

**УФТАНУ** *ф.* 1) *к.* **уфылдау** (*1 мәгъ.*)

2) Зарлану, авырсыну. *Бөтен уефикере үз эчендә генә – зарланырга яки уфтанырга бер дә яратмый.* Ә.Еники. – *Урта мәктәп кенә шул, – диде Вәли, уфтанып.* Ф.Җамалетдинова

3) Үкенү, үкенеп борчылу. *Ләкин барыбер манма су булды, тик моңа тамчы да уфтанмады – чөнки барыбер көне җылы, матур иде!* М.Вәлиев. *Татарча бер сүз белмәгән оныгын сөйгән әбинең: «Үзебез генә гаепле, балачакта татар теленең, татар кешесенең беркемнән дә ким булмавын аңлата белмәдек», – дип уфтанганын күрдем.* Р.Рашат // Гомумән борчылу, пошыну. *Кеше үз тормышында бер генә якын кешесен югалтса да, гомере буе уфтана, онargын алмыйча иза чигә.* М.Хәсәнов. *Алар, хәзер нишләргә, ничек тормышка җайлашырга, ни кылырга, дип кайгырышып, уфтанып та утырдылар.* Х.Камалов

**Уфтана башлау** Уфтанырга тотыну. *Казанга килүенә ел тулганчы ук, 1908 елның 23 июнендә шагыйрь бу даирәдән зарлана, уфтана башлый.* Р.Фәтхрахманов

**Уфтанып алу** Бераз гына яки бер тапкыр уфтану. – *Их, әткәй дә кайткан булса! – дип уфтанып алды Әхтәм, тәбикмәк ашарга утыргач.* Ә.Моталлапов. *Әнисе бу хәлгә бераз уфтанып алды.* Ф.Яхин

**Уфтанып йөрү** Һаман, гел уфтану. *Мөслах карт, чир әләкмәгәнгә уфтанып йөри торгач, бая әйткәнебезчә, уттай кызышып уянды.* Ф.Яруллин

**Уфтанып кую** Бер тапкыр уфтану. *Әби дә авыр сулап уфтанып куя: – Мидхәтем якынрак иде шул.* Р.Габделхакова. *Әнием: «Укырга уйлый икән һаман», – диде дә, тавышын чыгармый гына, күкрәк төбеннән уфтанып куйды.* Г.Якупова

**Уфтанып тору** Әле, сөйләү моментында уфтану. *Волгоград кунагы уфтанып торды да башлыгын эзли башлады.* Кызыл таң

**УФЫЛДАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **уфылдау**. – *Ярар, – дип, хатыны урындыкны уфылдатып урыныннан торды.* М.Галиев

2) Өреп яки суырып һава агымы барлыкка китерү. *Аның тартуы да картларчарак: төтенен суыра да уфылдатып чыгарып өскә өрә.* Р.Мирхәйдәров

**УФЫЛДА́У** *ф.* 1) Берәр физик яки рухи халәттән авыр, тирән сулап көрсенү, уф дип кую. *Зөһрә апаның уфылдаганын, ахылдаганын тыңлап барган Хәкимҗан абзый: – Әкрен! Кеше ишетмәсен! – дип җикеренде.* А.Гыйләҗев

2) *к.* **ухылдау** (*4 мәгъ.*). *Шул төн кошы уфылдый...* Н.Сафина. *Төн уртасында ябалакмы шулай уфылдый?* Р.Камал

3) Тирән һәм авыр итеп сулау; уфылдаган тавышлар чыгару (хайваннар тур.). *Хәләф Борһанович[ка] --- яшь үләнгә туйган сыерның уфылдаганы, кәҗәләрнең мырт-мырт күшәгәне, канат астыннан туганнары этеп чыгарган каз бәпкәсенең пипелдәп әнисен чакырганы ишетелде.* Т.Гарипова. *Уенчыклар әрҗәсеннән, уфылдый-уфылдый, Аю килеп чыга: – Сәгать ничә?* С. Гаффарова

4) *күч.* Көчле һава агымы, шау тудыру; шаулау; шаулаган тавыш чыгару (җил, дулкыннар тур.). *Диңгезнең, суык тидергән кәефсез карт кебек, әкрен генә уфылдаган, ыңгырашкан тавышы ишетелә иде.* Ш.Камал. *Җылы җилләр – минем холкым, сине сагынып уфылдый.* Р.Әхмәтҗанов

5) *күч.* Уф дигәнгә охшаган тавышлар, авазлар чыгару. *Машина чекелдәде, тәкелдәде, уфылдады.* Г.Афзал. *Якыннан гына, уфылдап, поезд үтеп китә.* А.Гыйләҗев. *Кыскыч, каргаборын, чүкеч кебек эш кораллары үзләренең чиратын көтә. Менә алагаем өргеч уфылдый, гыжлый – үзенең вазифасын башкара.* Р.Низамиев

6) Кайгыру, борчылу; үкенү, зарлану. *Дөрес, Сәхипҗамал җиңги елак хатыннар кебек бертуктаусыз уфылдамый, сукранмый, сыкранмый һәм шуның белән Гөлшәһидәнең күңелендәге борчуны бермә-бер арттыра иде.* Г.Әпсәләмов

**Уфылдап алу** Бераз, бер тапкыр уфылдау. *Карт тагын уфылдап алды, тагын ике кулы белән башына ябышты: – Алла каргышы төште миңа, балакайлар, Алла каргышы...* Н.Акмал

**Уфылдап йөрү** Озак вакыт дәвамында уфылдау; гел, һәрвакыт уфылдау. *Редакция коридорларында да: «Кичә бәрәңгене алып бетердек, чыгуын шәп чыга, ну бүген тәннәр авырта», – дип уфылдап йөрүчеләр байтак.* Татарстан яшьләре

**Уфылдап кую** Бер тапкыр уфылдау. *Акланырга сүз тапмады Моназыйр, уфылдап кына куйды.* М.Хуҗин. *Янгын хәлләрен ишеткәч, Гөлфия уфылдап куйды.* М.Маликова

**Уфылдап тору** Даими, әледән-әле яки шактый вакыт уфылдау; әле, хәзер уфылдау. --- *бер түшәмгә, бер идәнгә, бер тәрәзәгә карап шактый уфылдап торгач, Нәҗип, кызарып, Хамисәгә борылды һәм, кипшенгән иреннәрен ялап, нәрсәдер мыгырдый башлады: – Хамисә... син әлләни уйлый күрмә... мин...* Ә.Дусайлы. *Бу әкәмәткә шаккатып уфылдап торганда, әлеге күренешне аңлатып китүче җәяүле дә табылды ---.* Сәхнә

**Уфылдый башлау** Уфылдарга тотыну. *Ресторан пешекчеләре әзерләгән барча нигъмәткә, берсен дә рәнҗетмичә, игътибар күрсәтә торгач, өчесе дә, сабаннан хәлсезләнеп кайткан кешеләрдәй, авыр сулый, уфылдый башладылар.* Т.Галиуллин. *– О-о-о, ү-ү-ләм... э-э-э, а-выр-та-а... үләм... – дип уфылдый башлаган ул, аларны күрүгә.* Р.Вәлиев

**УФЫЛДАШУ** *ф. урт. юн. к.* **уфылдау**. *– Саумы, җир! – диеп, Күтәрүгә авыр сыртларын Уфылдашып сала ярларга. Шул ярларга бәрелеп чалара, Якты кояш ватыла аларда.* Р.Сәйфетдинов

**УФЫРУ** *ф. к.* **уфылдау**. *Карт ниндидер тирән сагышлану белән уфырып тын алды.* А.Хәлим. *Нигәдер: «Ничек дөньяларында яшәп бетәргә хәзер? Их-ма, хәсрәте», – дип уфырмыйсың әле син.* Н.Гыйматдинова

**Уфыра башлау** Уфырырга тотыну. *Барыгыз да уфыра башласагыз нишләрмен ---.* Кызыл таң

**Уфырып йөрү** Гел, һаман уфыру, озак вакыт дәвамында уфыру. *Әнисенең елап туктагач уфырып йөрүенә түзә алмаган Әмир: – Җитте сиңа үз-үзеңне бетереп йөрергә! Гаеп Сәвиядә, көтә белмәгән, – дип әйтеп салды.* Т.Галиуллин

**Уфырып кую** Бер тапкыр уфыру. *Хатын, Алексей савытына сөт өстәгәндә, иелебрәк елмайды да: – Арту көтәсезмени? – дип уфырып куйды.* Х.Камалов

**УХ** *ы.* 1) Көчле теләкне белдергәндә, шул мәгънәне тагын да көчәйтү өчен кулланыла. *– Ух, малайлар, итле аш ашыйсы килә! – дип куйды ачлыкны авыр кичерүче Расих.* Ф.Яруллин

2) Соклану, шаккату, ис китү, гаҗәпләнү, шатлану, сөенү хисләрен белдергәндә көчәйтү төсмерен өстәп кулланыла. *– Ух, нинди биек! – ди Газинур һәм аяклары, куллары белән усакка кысла кебек ябыша.* Г.Әпсәләмов. *Ух, яратам кунакка йөрергә!* Х.Ибраһим

3) Ярсу, ачулану, тиргәү, рәнҗү, зарлану хисләрен тирәнрәк, көчлерәк итеп белдерү өчен кулланыла. *Ух, бөтенесен ватып-кырып, томалап бетерәсе иде шуларның!* А.Гыйләҗев. *У-ух, кеше түгел син, абый!* З.Мәхмүди

4) Канәгатьләнү хисенә тирән эмоциональлек өстәү өчен кулланыла. *– У-ух, шәп булды бу! – диде ул судан чыккан эт кебек кагынып һәм миңа эндәште.* З.Мәхмүди. *Ух, Аллага шөкер, бер-бер хәл булдымы әллә, дип торам.* А.Фәләх

5) *к.* **уф** (*2 мәгъ.*). *Бу юлы ул үзе дә, ох, өшим, ух, туңам, дип калтырана кебек.* Н.Дәүли. *Ух, баш мең кыйпылчыкка ярыла-а!* Н.Гыйматдинова

6) *к.* **уф** (*3 мәгъ.*). *– Ух, харап булдык... – дип кенә әйтә алды.* С.Сабиров. *Ух, ычкынды кабахәт.* Р.Сәгъди

**У́Х ИТҮ** *ф. к.* **ухылдау**. *Әхмәт тә ух итеп куя.* Ф.Яруллин. *Ах иткәннәр, ух иткәннәр, көчкә тартып чыгарганнар моны.* М.Маликова

**УХЛА́У** *к.* **ухылдау**. *Агуны бернәрсә белән дә катыштырмаганлыктан, йөрәгенә барып ябыша да калтырап егылып китә, тәмам телдән калып бер-ике мәртәбә ухлап кычкыра да җан тәслим итә.* Г.Камал. *Бусагалар көтә сине сыкрап, Син, дип ачам ишек киләсен, Ухлап карт ябалак күтәрелсә Ботагыннан корган тупылның.* Л.Янсуар

**У́Х-ПУХ** *ы.* Симезлек, авыру яки башка сәбәптән авыр тын алуны, ухылдауны белдерә. *Әнә теге фил булыр, ди Алла, каушавы белән борын очына кыстырып килгән бүрәнәсен дә ташларга онытып, ух-пух басып торган филне күрсәтеп.* Г.Гобәй

**У́Х-ПУХ КИЛҮ** *ф. к.* **ухылдау**. *Тегендә-монда борын төртеп, базарына-мазарына барып печән, солы эзләп, ух-пух килеп йөрүне җене сөйми Гыйрфан мулланың.* С.Поварисов. *Галиәсгар мондый дорфалыкны көтмәгән иде, ул башта сүзсез торды, ух-пух килде, аннан соң каты тавышы белән: – Аһ, атаңа нәләт! – дип кычкырды.* Р.Батулла

**УХУАТ** *и. рус* Чуен, чүлмәк һ.б.ш.ны мичкә кую һәм алу өчен, озын агач сапка утыртылган ике япьле тимер каптыргычтан гыйбарәт әсбап. *– Иделдән*

*дисең? – хатын ухуатын идәнгә ыргыта, нәфрәтләнеп, ачуына буылырдай булып, Жуков каршына килеп баса.* Р.Мостафин. *Гөлнәзирә ухуатын мич авызына кертер-кертмәс килеш аптырап калды.* М.Әмирханов

**УХЫЛДАП** *рәв.* Авыр итеп; бар көчкә

**УХЫЛДА́У** *ф.* 1) Симезлек, авыру, хәлсезлек аркасында авыр итеп тын алу. *Бераздан, ухылдап, хәзрәт килеп керде.* М.Әмирханов. *Аннары ручкасын өстәлгә атып бәрде: – Юк, куя алмыйм, – диде ул, юри бүлмә буйлап йөргән тоткан хәлдә ухылдап йөрийөри.* Ф.Садриев

2) Сыкранып, сызланып, хәлсезләнеп ахылдау; ах-вах килү. *Ухылдап менеп җиткән Исхакны да алар игътибарсыз калдырмады.* А.Гыйләҗев. *Шәмсун, авыр ухылдап, йөзтүбән әйләнеп ятты.* А.Вергазов

3) Көчле шаулау (дулкыннар, җил һ.б. тур.). *Идел үзенә хас ритм белән ухылдап сулыш ала.* Р.Низамиев. *Эре йолдызлар астында төнге Һинд океаны ухылдап ята.* М.Галиев

4) Ух дигәнгә охшаган тавыш белән кычкыру (ябалак тур.). *Көне-төне ухылдап, бар дөньяга моң-зарын таратучы ябалак та, төн буе гашыйк җаннарга мәдхия җырлаучы сайрар кошлар да тынып калды.* Г.Тарханова // Шундый тавышлар чыгару (техника һ.б. тур.). *Вокзалда ташкүмер исе, манёвр паровозларының ухылдавы, су алып торган паровозның чыжылдавы, гармун, җырлау, елау, команда тавышлары иде.* М.Мәһдиев

**Ухылдап алу** Аз гына ухылдау; бер тапкыр ухылдау. *Мәче башлы ябалакның ухылдап алганы да ишетелә.* Т.Миңнуллин. *Ара-тирә ыңгырашып, ухылдап ала.* Г.Гыйльманов

**Ухылдап җибәрү** Кинәт ухылдый башлау. *Аннары ул тирәкләр күләгәсенә таба атлады, әмма кинәт кенә туктап калды һәм кулларын ян-якларына чапкалап ухылдап җибәрде: – Ах, кадалсын ла иде!* Э.Касыймов

**Ухылдап йөрү** Озак вакыт дәвамында ухылдау; һаман ухылдау. *Рәсәй буйлап үч Соңгы сулыш белән Ухылдап йөри ---.* Ф.Яхин

**Ухылдап кую** Бер мәртәбә ухылдау. *Бер кисәге нәкъ чиләккә төште бугай – чиләк әллә нинди кызганыч тавыш чыгарып ухылдап куйды.* А.Тимергалин. *Кайдадыр ябалак ухылдап куя, яисә башка бер кош тавыш биреп ала да янә бар җир тынып кала.* З.Мурсиев

**Ухылдап тору** Даими, бертуктаусыз ухылдау; хәзер ухылдау. *Төне буе тонык кына ухылдап торган Идел флотилиясе пароходлары да, моторлы һәм моторсыз көймәләр дә – барысы да каядыр посканнар.* Г.Әпсәләмов. *Әнә бит нindидер сәер гөрелте тавышы ишетелә, бөтен тирә-як гүләп, ухылдап тора.* Г.Гыйльманов

**Ухылдый башлау** Ухылдарга тотыну. *Әле яңа гына тыныч дулкыннар йөгертеп уйнаган назлы диңгез дә, куркыныч кара төскә кереп, дулый-дулый чайкала, ухылдый башлады.* З.Мәхмүди

**УҺУ** *ы.* 1) Көтелмәгән, кинәттән булган нәрсәгә шаккатуны, гаҗәпләнүне, соклануны, хуплауны һ.б. белдергәндә кулланыла. *Гармун тавышына, әсәреп, Хәкимҗан килеп керде: – Уһу, болай булгач, музыкантлар күбәйде, – диде ул, шатланып.* М.Мәһдиев. *Уһу, нинди зур кишер таптым!* Р.Батулла

2) Кемнеңдер булдыклылыгына, тапкырлыгына соклану, гаҗәпләнү, канәгатьлек белдерү өчен кулланыла. *Юлдашы --- күршеләргә бераз колак салып торды да: – Уһу-у, француз әдәбиятын тикшерүгә күчкән ич болар! – диде.* Т.Әйди. *– Егерме алты ел колхоз председателе булдым мин, парин. – Уһу! Бу кадәр стажлы председательләр сирәктер ул.* Р.Төхфәтуллин

**УҺЫЛДА́У** *ф.* 1) Авыртуга түзә алмыйча һ.б.ш. сәбәпле сыкранган аваз чыгару, авыр итеп сулау. *Бераздан уһылдап кайтып кергән Габделхакның буранын уйнатты апа.* Г.Гомәр. *Авыру бала уһылдый*

2) Кайгыру, борчылу, зарлану. *[Әни] Еларга җитешеп, нишләргә белмичә уһылдарга, арлы-бирле сугылырга тотына: – Ходаем, дөньяның асты өстенә килә, тыннар буыла.* Г.Бәширов

**Уһылдап алу** Бераз, берара уһылдау

**Уһылдап җибәрү** Кинәт уһылдый башлау

**Уһылдап кую** Уһылдау авазы чыгару, бер тапкыр уһылдау. *Сөембикә аптырабрак торды да уһылдап куйды.* Г.Бәширов. *Мәргән авызындагы укны җиргә төкерде. Вәзир халкы уһылдап куйды.* Батулла

**Уһылдап тору** Гел, берөзлексез яисә әледән-әле уһылдау; әле, хәзер уһылдау

**Уһылдап чыгу** Билгеле вакытның башыннан ахырына кадәр уһылдау. *Ул төннәр буе ыңгырашып, уһылдап чыга иде.* Ф.Бәйрәмова

**Уһылдый башлау** Уһылдарга тотыну. *Өстә нидер дөберди, чатырдый, уһылдый --- башлый.* Ф.Бәйрәмова

**УҺЫЛДАШУ** *ф. урт. юн. к.* **уһылдау** (*2 мәгъ.*). *Җыелган халык үзара нидер сөйләшә, уһылдаша*

**Уһылдаша башлау** Уһылдашырга тотыну. *Авыр хәлдәгеләр уһылдаша башлады*

**Уһылдашып алу** Бераз, берара уһылдашу

**УЧ** *и.* 1) Кул чугының бармакларны бөгеп ябыла торган ягы; кул аркасының кире ягы. *Низам бер минутка трубканы учы белән каплап торды.* В.Имамов. *Үзе дә сизмәстән, нәни учы белән бу матур гөл чәчәгенең алсу керфекләрен иркәләп, сыйпап куйды.* Г.Гыйльманов

2) Кул чугының тотып тору, тотып алу, берәр нәрсә салу, кую өчен савыт сыман җайланган рәвеше. *Габдерәшит карт, учы белән алып, суны кабып та карады: суы әйбәт, ят тәм юк, үзе салкын иде.* А.Тимергалин. *Бал кортын җиргә куя да учы белән туфрак алып, аның өстенә сала.* Д.Салихов

3) Учлап алынган әйбер микъдары. *Көненә бер мәртәбә бер уч арыш ярмасыннан пешерелгән аш эләгә.* В.Нуруллин. *Һәрбер учы йөрәкләргә Кысылган җир бу.* Г.Хуҗиев

◊ **Уч төбедәй** Бар яктан да күзгә ачык күренеп торган; кечкенә (территория, мәйдан тур.). *Дошман кулыннан сугышып алынырга тиеш булган уч төбедәй җирдән ул күзен алмады.* Г.Әпсәләмов. **Уч төбе кадәрле** Бик кечкенә, бик аз. *Мин шушы җирдә калам, уч төбе кадәр җирдә.* И.Юзеев. *[Илгизәр:] Нигә соң шушы уч төбе кадәр посёлокта кадалып ятасыз, әйдәгез Казанга!* Ф.Яруллин. **Уч (төбе) кычыту** Кыйнашасы килү; кыйнарга ымсынып тору. **Уч төбендә биетү** Үзенә хезмәт иттерү, буйсындыру; үзе теләгәнчә эшләтү. *Кәлимәт бәк әнә өч ханны уч төбендә биеткән.* М.Әмирханов. **Уч төбендәге кебек** Бик ачык булып (күренеп тору). *Иртәнге һава чиста, тын иде, һәм бөтен җир өсте уч төбендәге кебек күренеп ята иде.* Н.Фәттах. *Хәзер ул фара яктысында уч төбендәге кебек.* З.Мәхмүди. **Уч төбендә генә йөртү** Бик кадерләп тоту, хөрмәт итү, игътибар күрсәтү. *Алла боерып, күрешә-кавыша калсалар, моннан соң ул Рәмзияне уч төбендә генә йөртәчәк.*

Н.Әхмәдиев. *Шуңа күрә Мөслимәсен күз карасыдай саклый, уч төбендә генә йөртә иде.* Р.Габделхакова. **Уч төбендә тоту** Бик нык контрольдә тоту; ирек бирмәү; башкалар өстеннән баш булу, буйсындырып тору. *Дистә еллар буе ханлыкны уч төбендә тоткан элекке баш карачы Кәлимәтнең бертуган энесе ләбаса.* М.Әмирханов. *Ә икенчедән, ул бит әле бөтен илне уч төбендә тоткан КГБда зур чин били.* М.Вәлиев. **Уч төбен җылыту** Берәр төрле хезмәт өчен акча бирү. *Уч төбен җылыткач, бөтенләй башка төрле сөйләшә шул әнә.* Кызыл таң. **Уч төбе хәтле** *к.* **уч төбе кадәр**. *– Шуның белән киңәшегез әле, – диде Фәридун Фазлыев, уч төбе хәтле кәгазьгә бер-ике сүз язып, Нәҗипкә тоттырды.* А.Гыйләҗев. **Уч төбе чаклы** *к.* **уч төбе кадәр**. *Бу – аның иң беренче бүләге: «Яшьлек дустыма» дип аталган, гади дәфтәр калынлыгы, уч төбе чаклы кечтеки генә китабыннан монысы.* Р.Хәмид. *Миңа, өйләнгән кешегә, уч төбе чаклы бер раскладушка гына сыя торган тар подвал булды.* Р.Батулла. **Уч тутырып** Бик күп итеп. *Мин үстем, һөнәрле булдым, айга ике тапкыр уч тутырып акча алам.* М.Маликова. *Башка берәү аның кебек җәфа чиксә, уч тутырып акча алыр иде.* В.Имамов. **Учында кысып тоту** Берәр нәрсәне исәпләп кенә тоту; акчаны бик саклап тоту, акчага сакчыл мөнәсәбәттә булу. *Минһаҗ бабасы акчаны учында кысып кына тота, балта осталарына да акчаны улы Вәсил түгел, үзе бирә торган иде.* Г.Ахунов

**УЧАК** *и.* 1) Ачык җирдә ягылган утын, чыбык-чабык һ.б.лар өеме. *Ул кичтә, учак янында, табигать матурлыгы турында дулкынланып сөйләвегез әле дә исемдә.* Л.Ихсанова. *Аста әле учак янында кайнашкан кешеләрне яхшы күрергә була, чишмә челтерәве дә ишетелеп-ишетелеп китә.* Ф.Бәйрәмова

2) Казан асты; мичнең казан астына ягыла торган урыны һәм шунда ягылган ут. *Ул учак янына килде, ишеккә арты беләнрәк торган кызны кочып алды, күзләренә карады.* Н.Фәттах. *Йөзен китерергә күмер күп куймадым, шулай да, сәгатьнең минутлыгы дүрткә җиткәч, мич капкачын ач та, күмерләрне кече учакка күчер, яме, кызым.* Н.Кәримова

3) *күч.* Туган, туып үскән җир, йорт. *Үз учагын, илен яклап, Күтәргәндер ул көр тавышын.* Г.Хәйруллин. *Үз учагына талпынып, канатланып кайтып кергән иде [Булат].* Я.Зәнкиев

4) *күч.* Күңелгә якын кешеләр (әти-әни, туганнар, балалар) тупланган урын; кешенең күңеленә рәхәтлек бирә торган җылылык, яктылык чыганагы; гаилә җылысы. *Монда җыелган барча иргә дә гаилә учагы, хатыннары илә сабыйлары җитми.* В.Имамов

5) *күч.* Файдалы казылмаларның күпләп чыгарыла торган урыны. *«Козгыннар оясында» [әсәрендә] алынган кешеләр язучының шуннан 7–8 еллар элек Донбассның күмер учакларында эшләп йөргәндә күргәннәреннән алынып бирелгән иделәр.* Г.Нигъмәти

6) *күч.* Нәрсәнең дә булса барлыкка килү, таралу урыны, үзәге, чыганагы. *Дөньяда иң беренче цивилизация учаклары Кече Азиядә һәм Төньяк Африкада барлыкка килгән.* Н.Фәттах. *Еш кына теге яки бу өлкәдә барлыкка килгән һәм үскән мәдәният учаклары, без белеп тә бетермәгән сәбәпләр нәтиҗәсендә, эзсез юкка чыкканнар.* Р.Әхмәтьянов

7) *күч.* Нинди дә булса хис-кичерешләр чыганагы, тупланышы. *Хәтер учагындагы кузлар кабынды да сүнде, кабынды да сүнде.* Н.Әхмәдиев. *Күңелендә сүнәр-сүнмәс кенә пыскып торган өмет учагына әйтерсең лә зур бер чиләк бозлы су ордылар...* Г.Галиева. *Сәбилә Хәербар белән очрашканнан соң үзендә рәхәт җиңеллек тойды, күңелендә шатлык учагы кабынгандай булды.* З.Мурсиев

**УЧАКЛЫК** *с.* **1.** Учак ягарга, бер учакка җитәрлек. *Карт, авызын ачып, икенче җөмлә әйтергә җыенганда, утын яра торган бүкән янында тәгәрмәч, тәртәләрдән учаклык утын гына калган иде.* М.Мәһдиев. *Кызларга инештән су, сырттарак үскән агачлар арасыннан бер учаклык коры ботаклар җыеп алып килгәч, Глеб киңәш-табыш итә башлады ---.* Т.Әйди

**2.** *и. мәгъ.* 1) Учак ягарга яраклы утын. *Каенсарда каен беткән, Усаклыкта усак юк. Имәнле имәнсез калган. Урман эзе – учаклык...* Ш.Галиев. *Учаклык ваклап кую*

2) Учак яга торган урын. *Күлнең аръягындагы учаклыкта каргалар кыштырдап-шыбырдашып куялар.* М.Хәбибуллин

**УЧАР** *и. фарс.* 1) Базар, базар мәйданы // Җыелу урыны. *Учарга җыелу*

2) Тармак. *Нәсел агачымның тамыры учар, Тармаклары йөзләр, меңнәрдер.* Р.Гарифуллина

3) Бер урында үскән агачлар төркеме. *Еракта каен учары күренә*

**УЧАРЛАНУ** *ф.* Тармаклану, җәелү. *Безнең урам буендагы агач бакчасына, әллә андагы яман да учарланып үскән шомырт агачына, әллә карт миләшкә, сандугач ияләнгән иде.* Г.Бәширов

**Учарлана бару** Торган саен күбрәк учарлану. *Үсеп утырган күп тармаклы агачны күз алдыгызга китерегез. Әлбәттә, ул кояшка, яктылыкка, җылыга омтыла. Ләкин аның үсүе, тармаклана, учарлана баруы өчен бу гына җитми.* Ф.Хөсни

**Учарланып бетү** Бик нык учарлану

**Учарланып тору** Туктаусыз учарлану; әле, хәзер учарланган булу. *Еракта Ботан бакчасының зәңгәрсу яшел таллары тоташ-тоташ учарланып тора.* Т.Нурмөхәммәтов

**УЧАРЛЫ** *с.* Тармаклы; җәелгән, тармакланган. *Учарлы өянкеләрнең юан кәүсәләре, астагы ботаклары да томан эчендә калган.* Ф.Садриев. *Кармыш чишмәсенә бара торган тыкрыктагы учарлы шомырт агачы ышыгында шулар, җыен тузга язмаганны бар итеп, әңгәмә куерталар.* Х.Батыров

**УЧА́СТОК** *и. рус* 1) Төзелеш, хуҗалык алып бару һ.б.ш. берәр максат өчен билгеләнгән җир мәйданының аерым өлеше; кишәрлек. *Юкса 1975 елда язучыларга бакча участоклары биргәч, бергә-бергә йорт салу мәшәкатьләре белән йөргән идек.* Ф.Яруллин. *Укучылар җәйге каникул чорында мәктәп яны тәҗрибә участогында хезмәт чыныгуы алалар.* Г.Гәрәева

2) Масштаблы зур территорияне биләгән бер урыны, өлеше, кисәге. *Совет Армиясе аерым участокларда гына түгел, бик зур Совет-Герман фронтының буеннан-буена диярлек һөҗүм итә.* Г.Әпсәләмов. *Стратегик яктан аеруча әһәмиятле Ленинград – Мурманск тимер юлының кайбер участокларында фин чикләренә нибары ярты чакрым гына.* А.Хәсәнов

3) Нинди дә булса эшчәнлек өлкәсе, тармагы, сферасы. *Партиягә тугрылыклы кеше буларак, аңа идеология эшенең теләсә кайсы җаваплы участогын ышанып тапшырырга мөмкинлеге әйтелгән.* Р.Мостафин

4) Нинди дә булса максат өчен оештырылган административ-территориаль

яки җитештерү бүлеге. *План буенча ишек ачылуга, участок комиссиясе председателе Әнвәр абый беренче сайлаучыларны каршылап речь сөйләргә тиеш иде ---.* М.Мәһдиев. *Соңыннан, күп кенә вакытлар үтеп, кан басымым нык кына күтәрелгәч, үзебезнең участок табибәсен чакырдым.* С.Ибраһимова

5) Полиция бүлеге һәм шул учреждение урнашкан бина. *Бөтенесе качты, әмма ике иптәш белән мин эләктем. Өч көн участокта ятып чыктык.* М.Мәһдиев. *Берничә сәгать эчендә шәһәр полициясе коралсызландырылды, участоклардагы кораллар да алынды, аның белән халык ополчениесе, халык милициясе коралландырылды.* М.Хәсәнов

**УЧЁТ** *и. рус* 1) Нәрсәнең дә булса булу-булмавын, исәбен ачыклау, тикшерү, барлау эше. *Почмактагы сары кибетне учётка япканнар.* А.Гыйләҗев. *--- дөрес тәрбия булмау, зоотехния учёты төгәл алып барылмау аркасында, сиксән баш терлекнең 1975 елда бөтенләе белән бетүе ачыкланды.* Т.Нәҗмиев

2) **учётта** *у.-вак. кил.* Берәр нәрсәнең исәпле, санаулы булуы турында. *Ел ахырынача тәмамлыйсы төзелешләр күп. Һәр кубометр такта учётта.* М.Маликова. *Колониянең һәр метр җире төгәл учётта.* А.Хәсәнов

3) Аерым социаль группа, сәяси партия, һөнәр һ.б.ш. вәкилләрен теркәү системасы. *Хәрби учёт*

◊ **Учётка алу** Кемне яки нәрсәне дә булса исәпкә алу, исемлеккә кертү, теркәү, регистрацияләү. *Хәзер генә сельсоветтан килеп, әйберләребезне учётка алып киттеләр.* Т.Гыйззәт. *Иртәгә үк ул егет янына үзем барырмын, учётка алырбыз, шефлар беркетербез.* Ф.Яруллин. **Учётка басу** *к.* **учётка керү**. *Икенче көнне үк военкоматка барып учётка бастым.* Г.Галиев. **Учётка керү** Исәпкә теркәлү, исемлеккә язылу, регистрацияләнү. *– Гафу итегез, комсомол ячейкасы секретаре сез буласызмы? – диде Булатов. – Миңа учётка керергә кирәк иде.* А.Алиш. *Мин сиңа, кәбәм, учётка кермәгән унҗиде баш сыер, илледанә тана һәм дә йөз илле катыборынны калдырам.* А.Гыйләҗев. **Учётка кертү** *к.* **учётка алу**. *Рушадның военкоматка учётка кереп кайтканнан бирле эшләгән бөтен эше бик гади: иртән ишекне каерып ачып, баскыч төпләрен чистарта.* М.Мәһдиев. *Беркөнне хатынын авыл советына учётка кертеп кайтып килгәндә Галия --- очрады.* Г.Галиев. **Учётта булу** *к.* **учётта тору**. *Элек акчаны ничек «сугалар» иде? Учётта булмаган, хисапка кермәгән продукция: мебель, келәмнәр, кием-салым, шәраб, коньяк, хәтта ювелир эшләнмәләр ясап.* Р.Мирхәйдәров. **Учётта тору** Исәптә тору, исемлектә, исәптә булу, саналу. *Ләлә белән Һаҗәр икесе ике комсомол оешмасында учётта торалар иде.* Г.Әпсәләмов. *Поезд нәкъ расписаниедә билгеләнгән вакытта килеп җитте, әмма анда инде син юк идең; Казанда төшеп калып, үзең учётта торган хәрби комиссариатка китүеңне әйттеләр.* С.Сабиров. **Учёттан төшерү** Исемлектән алу, исәптән төшерү. *Яшьләр беренче, икенче көннәрне Аннаны эшеннән бушату, учёттан төшерү артыннан йөрделәр.* Г.Галиев. *Шулай итеп, Булатны учёттан төшереп, акылдан язучылар исемлегеннән сызып ташладылар һәм бүлнистән якты дөньяга чыгардылар.* З.Хәким. **Учёттан төшү** Исемлектән, исәптән чыгу. *Соңгы көнне шулай ук учёттан төшеп кайтырга туры килде.* М.Мәһдиев

**УЧЁТЧИК** *и. рус сөйл. к.* **учётчы**. *Баруым – яңа фабрикага кереп булмасмы, дигән өмет белән иде, һәм, бәхетемнән димме, мине фабрикага учётчик итеп алдылар.* Ә.Еники. *Галимулла абыеңны тап. Шахразый абый әйтте диген, тиз генә кәнсәләргә бригадирны, учётчик кызны, амбар мөдирен чакыртсын.* Р.Бәшәр

**УЧЁТЧЫ** *и.* Гадәттә, җитештерү тармагында әзер продукцияне, үтәлгән эш күләмен һ.б.ш.ны исәпкә алып теркәп торучы хезмәткәр. *Икенче бригада бригадиры белән учётчы өстеннән акт төзелде, актка кул куелды.* Н.Фәттах. *Анысы үзе дә күктән төшмәгән – шул ук фермада гап-гади учётчы гына.* Р.Габделхакова

**УЧИ́ЛИЩЕ** *и. рус* 1) 1917 елга кадәрге Россиядә: дәүләт карамагындагы уку йорты; мәктәп. *Мәдрәсәдә гыйлем эстәвен ташлап, ул бер араны Ростов шәһәрендәге реаль училищеда укып ала.* М.Хәсәнов. *Мәктәп һәм мәдрәсәләр янындагы рус классларын күзәтеп тору халык училищелары инспекторларына йөкләнә.* Ә.Хуҗиәхмәтов

2) СССРда: тулы булмаган урта яки урта һөнәри белем бирә торган уку йорты. *Унны бетергәч, мин Саратов хәрби училищесына укырга барып кердем.* Ф.Яруллин. *Зәйтүнә Минзәләнең медицина училищесында үзе белән бергә укучы кызлар белән шәһәр үзәгендәге паркның күләгәле юлыннан узып бара иде.* М.Маликова

**УЧЛАМ** *и.* Бер учка сыйган яки сыярлык нәрсә, бер уч. *Аннары бер учлам коры үләнгә ут төртеп, түбәнгә ташлады.* А.Тимергалин. *Ул да булмый, бакча ягыннан кулына бер учлам кычыткан, урак тоткан әти күренә.* Р.Мөхәммәдиев

**УЧЛА́У** *ф.* Уч белән тоту, уч белән алу. *Кыз, иелеп, туфрак учлады.* Н.Гыйматдинова. *Бабай, сакалын учлаган килеш, аптырап, ишек төбендә тукталып калды.* А.Вергазов

◊ **Учлап калу** Алдану; бернәрсә дә ала алмау, бернәрсәсез калу. *Акча бирәләр идеме соң бабаңа? Әллә шул коры рәхмәтләрне генә учлап кала идеме?* Л.Лерон

**Учлап тору** Гел учлау; әле, хәзер, күз алдында учлау. *--- хәлфә абыебыз доганы кызганмый, иреннәрен тиз-тиз кыймылдатып, кулларын киң итеп җәеп --- дога кыла, --- бик канәгатьләнеп, сакалын да учлап тора.* А.Шамов. *– Алайсам, Ниса дөрес әйткән икән, – дип, әти алга чыгыбрак торган ябык ияген учлап торды ---.* Т.Нурмөхәммәтов

**Учлый башлау** Учларга тотыну. *Һәм имине җайлап, тоташы белән зур кулы белән учлый башлады.* Сөембикә

**УЧМА** *и.* 1) Урак урганда бер учка сыйган кадәр тотып кисеп алынган ашлык. *Шулчак Иргали учын тук башаклар кытыклавын тойгандай булды. Менә ул, күз ачып йомганчы, бер көлтәлек булып үрчегән учмаларын тигезләп җиргә сала.* М.Хәсәнов. *Сул кул арыш сабакларын бер учмага кай арада җыеп өлгерә дә, уң кулдагы урак кай арада учманы кисеп ала, күз дә иярми; камыллы җир өстендә арыш учмалары тезелешеп кала.* Р.Батулла

2) Бер тотам. *Печән учмасын бик нык бөтереп шәм әмәлләделәр.* Х.Камалов. *Аның йөзендәге бөтен хәрәкәт, мангаена төшкән чәч учмалары, косынкасының һәр шакмагы, фотоплёнкага төшкән кебек, күз алдымда торып калдылар.* Г.Рәхим

**УЧМАЛА́У** *ф.* Урганда, урак белән кисәр өчен, ашлык сабагын учка җыеп, учлап тоту. *Җир өстенә килеп җиткәч тә тегеңә чабата-оек кидерәм, кулына урак тотарга, арыш учмаларга өйрәтәм.* М.Гали. *Ураккайлар урдым*

*мин учмалап, Чүмәләләр куйдым ла ниргәләп.* Милли-мәдәни мирасыбыз: Мамадыш // Гомумән учлау, учлап тоту. *Текә урыннарда, егылмас өчен, нәзберек үләннәрне учмалап тотынып калам.* М.Галиев

**УЧМАР** *и. диал. к.* **учма**

**УЧМАРЛАП** *рәв.* Күп итеп, күпләп. *Урамда ишеп-ишеп кар ява. Җиле дә ярыйсы ук көчле. Искәрмичәрәк барсаң, ачык авызыңа учмарлап кар ыргыта.* Ф.Яруллин

**УЧМАРЛА́У** *ф. диал. к.* **учлау**. *Ул икенче кулы белән тирес өстен тырнап, астыннан юешләнеп торган җылы тирес учмарлады.* М.Әмир. *Елына миллионнан артык --- машиналар чыгарган СССРның үз халкы унар ел машинага чират торып, ахыр чиктә тиенләп җыйган акчасын, учмарлап, теге дөньяга алып китә иде.* Ф.Яруллин

**УЧРЕЖДЕ́НИЕ** *и. рус* Идарә, хуҗалык, сәүдә һ.б.ш. эшләрне алып бара торган, аерым хезмәткәрләр штаты һәм администрациясе булган оешма; тәшкилат. *Аркылы урамның ике ягына агач кибетләр, ашханәләр, учреждениеләр урнашкан, почта да шунда.* А.Гыйләҗев. *Кайсы дәүләт учреждениесенә, кайсы гына офиска кермә – шунда автоматлы сакчы.* А.Хәсәнов

**УША** *и. диал.* Басып мич башына менү өчен яки комган, киез итек кебек әйберләрне кую өчен җайланган тар такта, басма. *Җылына төшкәч, күзләр ачылып китте, һәм мин, мич буендагы ушага утырган килеш, үзем танып бетермәгән бер яшь кенә кызга карадым да таң калдым.* Ш.Маннур // Гомумән басма. *Врачлар, җылыга кертмәү хәерлерәк булыр, дигәнгә, гәүдәсен өйалдындагы ушага куйдылар.* Ә.Баян

**УШАНДАК** *терк. иск.* Шулай ук. *«Сөбханә» кычкыра кәккүк, ушандак Сак белән Сок, Әйтәләр «инне ән зәннә», ишетсәм – тәкатем юк.* Бәет. *Ушандак Борһан әфәнде, Габдрахман әфәнде, Ярулла әфәнде, Шәриф Камал, Сабир, Кәлимулла әфәнделәргә – һәр каюсына сәлам күндердем.* Гасырлар авазы

**УШАТ** *и. рус диал.* 1) Агач чиләк. *Ул --- чан эченә төшеп китте һәм, электән җайлап куйган такталарга басып, озын саплы лейка белән, чалтыратачалтырата, --- селёдка суын ушатка тутыра башлады.* Ш.Камал

2) Колаклы агач кисмәк. *Аннары, ләүкәдән төшеп, өстенә ике ушат салкын су аударды да, башына юеш сөлге урап, кулларына алдан ук әзерләп куелган иске бияләй киеп, яңадан ләүкәгә менде.* Г.Әпсәләмов

**УШБУ** *а. иск. к.* **ошбу**. *Кытай хикәяте ушбу урында тәмам булды.* Г.Камал. *Кәҗә, Сарык, күргәч ушбу тамашаны, Калды куркып – һәрберсенең ярты җаны.* Г.Тукай

**УШУ** *и. кыт.* Кешенең шәхесен камилләштерүне максат итеп куйган, нигезен фәлсәфә, әхлак, психофизика принциплары тәшкил иткән кытай милли көрәш сәнгате төрләренең гомуми атамасы. *Ушу буенча күп тапкыр дөнья чемпионы Ильяс Хөснетдинов Казанның 135 нче мәктәбе спортзалына урнашкан сайлау участогында илнең киләчәге өчен тавыш бирде ---.* Идел. *Парклар күп, анда музыка яңгырый, көн дәвамында карт бабайлар шунда ушу белән шөгыльләнәләр.* Ирек мәйданы

**УЫЗ** *и.* Хатын-кызның һәм имезүче хайваннарның тудырыр алдыннан һәм тудыргач та сөт бизләреннән бүленеп чыга торган, составы белән сөткә якын саргылт сыекча; угыз. *Чәйдән соң әни, Караборынны савып, бозавына уыз сөте эчерде дә, әнисеннән аерып, лапасның кечкенә бүлегенә япты.* Л.-Х.Таналин

**УЫЗЛЫ** *с.* Уыз катнашкан, уыздан арынып бетмәгән. *А. Иматдинов яшь бозауларга нинди вакциналар ясалырга һәм нинди витаминнар кулланылырга, яңа туган бозауларга беренче сәгатьләрендә үк уызлы сөт эчерү кирәклеге турында сөйләде.* Туган як

**УЫЛДА́У** *ф.* У-у итү, шуңа охшаш тавыш чыгару. *Өй дә зур умарта кебек уылдады, гөрләде.* Г.Исхакый. *Мотоцикл, уылдап, күзгә күренмәгән, гомер йөрелмәгән тирән чокырларга барып керә, аннан, сикерә-сикерә, кабат үз юлын дәвам итә.* Х.Ибраһим

**Уылдап алу** Кыска гына уылдау. *Хәйрулла карт --- бугазыннан каты тавыш чыгарып, нәкъ әтәч төсле уылдап алды.* М.Мәһдиев. *Аның машинасы гел уылдап ала.* Р.Батулла

**Уылдап җибәрү** Кинәт уылдый башлау. *Шулчак бер кош уылдап җибәрде*

**Уылдап кую** Бер тапкыр уылдау. *Кемдер уылдап куйды*

**Уылдап тору** Туктаусыз, гел уылдау. *Урамда көзге җил уылдап тора*

**Уылдый башлау** Уылдарга тотыну. *Кортлар бердән кузгалып китеп уылдый башладылар.* Г.Исхакый

**УЫЛДЫК** *и.* Җир-су хайваннары бүлеп чыгара торган бөртексыман күкәй. *Рига култыгында кышлаган елга балыклары Дуняс һәм Лиласте күлләренә язын уылдык чәчәргә кереп тулалар.* З.Зәйнуллин. *Өстәлдә чәчәкле тәлинкәләрдә ит, кәтлит, кыздырылган ипи телемнәре, кызыл балык, уылдык, кысла ише ризыклар һәм нибары бер шешә кызыл шәраб тора иде.* М.Маликова

◊ **Уылдык чәчү** Ачуланып ярсу, ачуына чыдаша алмыйча гауга куптару. – *Ник юкка уылдык чәчәсең әле син, дус кеше? – диде Илдус.* С.Сабиров. *Прокурор Миршаб --- сүзен дәвам итте: – Анда Кодрәтовның бабасыннан да өстәрәк утыручылар бар, --- хәзер аңлыйсыңмы Костаның нишләп уылдык чәчкәнен?* Р.Мирхәйдәров

**УЫНУ** *ф.* 1) *кайт. юн. к.* **уу**. *Шуннан соң үзем юынырга тотындым инде. Мунчала белән тәнемне бурлаттай кызарганчы уындым.* Р.Кутуй. *Дарулар белән уына-сөртенә озын кышларны исән үткәрә алса, хезмәт юлын башлаган Бакырлы авылына кайтып --- килергә, дигән уй белән язларны түземсезләнеп көтеп алды.* А.Хәйретдинова. *Кырмыска мае белән уыну*

2) *күч.* Берәр уңышсызлыкка очрагач, алдангач үкенү, нишләргә белмәү. *Атаклы мастерның куенына Мөнәвәрә генә бер мат кыстырып җибәрде. Әй уынды, әй уынды инде халыкара танылган мастер.* А.Хәсәнов. *И уындылар син киткәч. Бер эшләре бармый. Кире кайтыр, дип көткәннәрдер инде.* Л.Сабирова

3) *күч.* Нәрсә дә булса борчу сәбәпле яки эчке кичерешләрнең чагылышы буларак, бертуктаусыз кул-тән һ.б. хәрәкәтләре ясау, тынычсызлану, тик тора алмау; кыбырсу. *Эченә хәмер кереп, башына менеп, теленә төшсә, элеккеге комсомол сәркатибенә әйләнә дә куя. Бала-чага мәеле, урындыгында уына.* Т.Галиуллин

4) *күч.* Нидер эшләп маташу, казыну, бер тирәдә чуалу

**Уына башлау** Уынырга тотыну. *Кулларыннан җитәкчелек китсә уына башлыйлар*

**Уынып алу** Берара, бераз уыну

**Уынып тору** Һәрвакыт уыну; әле, хәзер уыну. *Мич янында Әлтафи уынып тора иде.* М.Мәһдиев

**УЮ** *ф.* 1) Нәрсәгә дә булса тишек тишү, нәрсәне дә булса юнып

чокырайту, чокыр, уем ясау. *Мин, талларны үткәч, бәке уелган якка карадым һәм анда, иелеп, чиләкләренә су алып торучы берәүне күрдем.* Ф.Хуҗин. *Шул арада чакрымга сузылган ике рәт такта корылма калкып та чыкты. Аларга тишекләр уелган иде.* М.Әмирханов

2) Эз калдыру, буразна ясау, еру. *[Тычкан], --- үләннәргә бәрелә-сугыла, тәгәрмәч уйган канау буйлап йөгерде.* Г.Гобәй. *Авыл урамындагы карлы юлда тирән эзләр уеп, тракторлар пожар сарае яныннан кузгалып киттеләр.* Ф.Хөсни

3) Җәрәхәтләү, яру. *Каен тузы кебек тиресен суеп, [кызның] Күкрәгенә йолдыз уйдылар.* Ә.Ерикәй. *Күгәргән нечкә тимерчыбык аның бармакларын уеп керде, авырту утлы ток булып бөтен тәнгә таралды.* Р.Вәлиев

4) Очлы, үткен нәрсә белән чокып язу, рәсем ясау. *Стенада җиде мең исем Гранит ташка уеп язылган.* М.Сафиуллин. *Күгәрчен сурәтен халкыбыз гомер-гомергә тәрәзә йөзлекләренә, капкаларга уеп ясаган, ул гаилә татулыгын, тигезлекне аңлаткан.* Ә.Мөхәммәтҗанова

5) Кием теккәндә яка, җиң турыларына керенте ясап кисеп алу. *Аклы ситса күлмәгеңнең Якаларын кем уйган.* Җыр

6) Кисү. *Урак итеп кемдер уеп алган, Урлап киткән Айның яртысын.* Р.Низамиев

7) Кислота тамчысы, утлы күмер һ.б.ш. берәр өслекне эретеп, көйдереп эз калдыру яки үтәли тишү

**Уеп алу** Бераз ую. *Үткен кылыч, таеп китеп, кулбашын уеп алды.* Х.Гали. *Кәшшаф пычак очы белән бармак битен уеп алды ---.* М.Әмирханов. *--- ашык-пошык урып кына ята идем, уч кырыен тагын уеп алдым.* Ш.Маннур

**Уеп бетерү** Бөтен җирен ую. *Нички ләр пыялага шулкадәр дә нәфис итеп уеп бетереп була икән соң?* Ф.Җамалетдинова. *Үсмер чакта шулай чормада көяләр уеп бетергән бер дәфтәргә юлыккан идем.* Сөембикә

**Уеп җибәрү** Кинәт ую, көтмәгәндә ую

**Уеп кую** Уелган хәлгә китереп калдыру

**Уя башлау** Уерга тотыну. *Аннары нәфис кәүсәгә, тузын гына телеп, нечкә сызыклар уя башлады.* М.Маликова. *Казаклар, Иртыш өстенә кереп, бозга бәке уя башладылар ---.* Ф.Бәйрәмова

**Уя бирү** Уюны дәвам итү. *– Идарәгә ник чакыртканнар? – диде Идрис. Ул, әйтмәсәң дә ярый дигәндәй, ак ботакның урта җирен һич көчәнүсез уя бирде.* Ә.Гаффар

**УЯЗ** *с. диал.* Уйсу, иңкү, чокыр булып торган. *Уяз җир*

**УЯЗЛЫК** *и. диал.* Уйсулык, иңкүлек. *Күзләремә ышанырга-ышанмаска белмим: уязлыкта поши бозавы ята.* Р.Мөхәммәдиев

**УЯНУ** *ф.* 1) Йокыдан уяу хәлгә килү, йокыдан тору. *Мин иртә белән уянганда, барысы да торган иде инде.* А.Алиш. *Дала һәм тауларда кояш нурлары белән иң беренче булып кечкенә кошлар уяна.* А.Нәҗми

2) Һуштан язып аңсыз ятканнан соң, сиземли, тирә-юньне тоя, фикер йөртә башлау, айну, аңга килү. *Сестра да аның күзләре ачылганны күрде. – Уяндыңмы? Ну, молодец! – ди-ди шатлана-шатлана сөйләнде.* Х.Камалов. *Бибисара өченче тапкыр уянганда да операция тәмамланмаган иде әле.* С.Сөләйманова

3) *күч.* Барлыкка килү, туу, яңару. *Әнә шул илһам дигәннәре соңгы вакытта минем күңелемдә сирәк уяна, бик сирәк.* А.Гыйләҗев. *Күптән күңелендә яшеренеп яткан өмет-хыяллары аның кинәт уянгандай булды, зур үзгәрешләр булачагын гүяки алдан ук тоеп, шуңардан ул ничектер җанланып, рухланып та китте.* Ә.Еники. *Бәлки, балагыз тугач, ирегездә аталык хисе уянгандыр.* Д.Салихов

4) *күч.* Хәрәкәткә килү, җанлану. *Җәйге челләнең кызгылт ут булып янып чыккан иртәнге кояшы белән дала уяна.* Г.Ибраһимов. *Моңа кадәр йокымсырап утырган җилбәзәк усаклар дерт итеп уяндылар да бөтен урманга шаулаша башладылар ---.* Г.Сабитов

5) *күч.* Аек, аңлы фикер йөртә башлау, активлашу, җанлану. *XIX йөз ахырында һәм XX йөз башында татар милләте --- дөнья прогрессы кирәклекләренә таба зур борылыш ясый. Халыкның социаль һәм милли аңы уяна.* М.Хәсәнов. *Мәктәптә уяна алмый калган акыл каядыр тирәндә йокымсырый, әмма, дөньяга үзеңне күрсәтәсе килеп, аек хис өстенлек итә.* М.Галиев

◊ **Уянмас йокыга китү** *к.* **уянмас йокыга талу**. **Уянмас йокыга талу** Үлү, вафат булу, бакыйлыкка күчү. *Ә без – Чәчкапта оборона эшләре алып барган 14 кеше – тәмам өлкән яшькә җиттек, кайберләребез безнең арада юк инде. Алар уянмас йокыга талдылар.* Җ.Фәйзи

**Уяна башлау** Уянырга тотыну. *Аның күңелендә сүнеп торган спортчы дәрте яңадан уяна башлады.* Г.Әпсәләмов. *Чү, кызларым уяна башлады.* Ф.Яруллин

**Уяна тору** Әледән-әле уяну. *Төннәрен төштә ит, йомырка, май, колбаса, каймак кебек нәрсәләр ашавымны күреп, саташа-саташа кат-кат уяна торгач, тагын да озая кебек гомер.* Ф.Баттал

**Уяна төшү** Бераз уяну; ныграк уяну. *Ул үз ирегеннән башка әйтелгән бу сүзгә тагы ныграк уяна төште.* Г.Ибраһимов

**Уянып алу** Кыска вакытка уяну. *Хәтта унбиш кенә тәүлеккә утыртуларына ризасызлык хисе дә уянып алды.* Н.Әхмәдиев. *Бер генә мизгелгә, хан тагы бер юньсезлек уйламый микән, дигән фикер дә уянып алды.* Р.Мирхәйдәров

**Уянып бетү** Тәмам уяну; барысы да уяну. *Барыбыз да уянып беткәч, көндәлек эшләр, мәшәкатьләр үз чиратында тезелешәләр ---.* А.Гыйләҗев. *Авыл әле уянып бетмәгән, каядыр сыер мөгрәгән, әтәчләр кычкырган тавышлар гына килә.* Р.Сәгъди

**Уянып җиту** Тәмам уяну. *Суганга да иртәрәк әле, бер өлеше генә тишеләә, шактые уянып җитмәгән була.* М.Маликова. *Уңда бер-ике катлы агач йортлар, мәчет һәм чиркәү манаралары белән Бишбалта бистәсе татлы йокыдан уянып җитә алмыйча ята иде.* Р.Кәрами

**Уянып килү** Акрынлап уяна башлау. *Сәгыйтькә җир өсте яңа йокысыннан уянып килә шикелле тоелды ---.* Н.Фәттах. *Май башлары иде булса кирәк, дөньяның яшәргән, табигатьнең яңа уянып килгән мәле.* Р.Мөхәммәдиев

**Уянып китү** Кинәт уяну. *Безнең идән астында нидер шыгырдаганга мин кинәт уянып киттем.* А.Алиш. *Һади кызган май исенә уянып китте.* А.Гыйләҗев

**Уянып кую** *к.* **уянып китү**. *Шунда нәфесем дә уянып куйды. Синең бу койрыгыңнан хатыныма бер дигән якалык чыгачак я бүрек.* А.Хәсәнов. *Менә шуннан соң инде кайбер тәнкыйтьчеләрнең компетентлылыгына бераз шик уянып куя.* Р.Миңнуллин

**УЯТУ** *ф.* 1) Кемне дә булса йокысыннан торгызу, йокысын өзү, бүлдерү, уянырга мәҗбүр итү. *Аның таяк*

*тавышы төнге авыр тынлыкка чумган бөтен коридорга яңгырый һәм күпләрне йокыларыннан уята булса кирәк ---.* Г.Әпсәләмов. *Гармун тавышы Сафураны уятты.* Х.Ибраһим

2) *күч.* Нинди дә булса уй-фикер тудыру, тойгы кузгату. *Яхшы пальто, күн түбәле каракүл бүрек --- кигән --- егет берьюлы аларның кызыксынуын уятты булса кирәк, шунда ук ике кыз, торып, Зөфәр янына килделәр.* Ә.Еники. *Байбаклар, әйтәм бит, күрер күзгә дә бик сөйкемле, беренче күрүдә үк күңелдә иң матур, иң җылы хисләр уята.* А.Хәсәнов

3) Уйга баткан, тирә-якка игътибар итмәгән кешенең игътибарын җәлеп итү, активлаштыру; айнытып җибәрү

4) *күч.* Хәрәкәткә китерү, җанландыру. *Кояш гөрләвекләр агызды, елгаларны боздан арчыды, кыш буе иңрәп йоклаган каеннарны уятты ---.* Г.Сабитов. *Уятты язны яңгыр – Төртеп чыкты бөреләр.* Р.Миңнуллин

5) *күч.* Нәрсәгә дә булса омтылыш тудыру, актив эшчәнлеккә этәрү, тарту; эшчәнлеген көчәйтергә этәргеч бирү, җанландыру. *Фәнни рисаләләр, гыйбрәтле милли хикәяләр, халыкны уятыр өчен язылган китаплар гомумда мәкъбүл була башлады, тагы яңы өметләр туа башлады.* Г.Исхакый. *Дәреслек укыр-өйрәнер өчен кызыклы, мавыктыргыч булырга, фикерләргә өйрәтергә, балада иҗат дәрте уятырга тиеш.* Ш.Галиев

**Уята башлау** Уятырга тотыну. *Беренче карауда кызгану тудырган бу кисек колаклы кеше анда чиркәнү тойгысы уята башлады.* Н.Фәттах. *Ул, сак кына килеп, як-ягына каранып, Гайсәне уята башлый.* Г.Каюмов

**Уята тору** Һәрберсен, бер-бер артлы уяту. *Сай фикерле, хезмәткә аек карамаучы офицерларның да җиңел генә үсүе, дәрәҗә алулары күңелендә гаделсезлек тойгылары уята торды.* Ф.Яхин. *Бу вакытта --- калын тавышлы агай --- кодаларны уята башлаган иде. Берәм-берәм уята торды, --- түшәк-мендәрләр түшәлгән бәләкәй арбага утыртышып, мунчага җибәрә барды.* Д.Булатова

**Уята төшү** Бераз уяту. *Декабрь азагыннан башлап озыная башлаган көннең февральдә күзгә күренеп үсүе күңелдә яшәү дәрте уята төшәдер, күрәсең.* Сөембикә

**Уятып бетерү** Барысын да уяту. *Берәү вагонда, таңнан торып: – Мин – крәстиян, иртән терлек ашатырга өйрәнгән! – дип, шаулап, башкаларны уятып бетерде дә үзе, тынычлап, күзләрен йомды.* Ш.Галиев. *Посёлоктагы пенсионерларны уятып бетердем.* Ф.Абдуллин

**Уятып җибәрү** Кинәт уяту. *Ул шундый тирән уйларга батып онытылып китте, ләкин кинәт көчле уйнаган музыка тавышы аны уятып җибәрде.* А.Алиш. *Гүя алар Рәфиснең күңел кылларына шыбырдап бәреләләр дә, зеңгелдәп, моңарчы йокымсыраган уйларын уятып җибәрәләр.* А.Вергазов

**Уятып җиткерү** Тәмам, ахырга кадәр уяту. – *Кем киеме ул? – дип, хатынын йокысыннан тәмам уятып җиткерде.* Ф.Яхин

**Уятып тору** Һәрвакыт, гел, әледәнәле уяту. *Фатих Кәрим кебек олы шәхесләргә мөнәсәбәт, аларның әһәмияте, бер урында катып калмыйча, һәрвакыт үзгәреп, бәхәсләр уятып тора.* Р.Вәлиев. *Ә менә кайбер публицистлар һәм сәясәтчеләр вакыт-вакыт «татар-монголлар изүе», «татар яулары», «татар ясагы» дип, татарларга карата тискәре караш уятып торалар.* М.Шәймиев

**Уятып чыгу** Барысын да уяту. *Әминә карчык кияве Рәис белән кызы Нәзирәне дә, күрше-күләндәге карт-карчыкларны да уятып чыкты.* Ф.Хәбибуллин. *Ул, иркәләп-назлап, туганнарның һәрберсен уятып чыккан.* Көмеш кыңгырау

**УЯ́У** *с.* **1.** 1) Йокламаган яки уянган, йокысыз. *Ул, күрәсең, күптән инде уяу иде, бары тик әдәп сакларга мәҗбүр булган өчен генә торырга кыймыйчарак ята иде.* Н.Фәттах. *Бар тараф тынып калган, Тирән йокыга талган. Тик кырда атлар уяу, Чыңлап куя кыңгырау.* Р.Миңнуллин

2) *күч.* Сизгер, сак; зирәк. *Шулай, кызым, ирләргә бервакытта да ышанып бетәргә ярамый, аш төрләндерергә яраталар алар. Уяу, сизгер булырга кирәк.* Ә.Еники. *Елга уртасына чаклырак исән-сау баралар, ләкин немец бик уяу, тирә-юньне яктыртып кына тора.* Х.Камалов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Йокламаган килеш, йокламыйча. *Мотаһир --- бераз уяу яткач, тышка чыкты.* Р.Кәрами

2) *күч.* Сизгер рәвештә, сакланып, саклык белән. *Дөрес, мин карчыга баласыдай бик сак, бик уяу утырам: егетнең бер сүзен дә, бер хәрәкәтен дә күздән ычкындырмыйм.* Ә.Еники. *Әти минем уяу вә сизгер йоклаганымны, тавышын ишетү белән сикереп торганымны, әлҗе-мәлҗе килеп ятмаганымны бик тә ярата иде.* К.Миңлебаев

**УЯУЛЫ́-ЙОКЫЛЫ** *рәв.* **1.** Йокылы-уяулы, ярым йоклап, ярым уяу хәлдә, йоклар-йокламас. *Төне буе уяулы-йокылы саташып чыккач, Булат, таң белән торып, папирос кабызды.* Ә.Гаффар. *[Арбада] Хәлим үзе уяулы-йокылы бара. Бөтенләй йоклап китүдән курка.* Г.Гыйльманов

**2.** *с. мәгъ.* Ярым йокылы, айнып җитмәгән, йокы белән өн арасындагы, йокылы-уяулы. *Хәтта төннәрен дә, авыру берәр нәрсә сорамый микән дип, уяулы-йокылы хәлдә, сагаеп, тыңланып ятарга гадәтләнде.* М.Галәү. *Данил уяулы-йокылы күзләрен бүлмә буйлап йөртте.* Ш.Галиев. *Икенче көнне иртүк уяулы-йокылы кәләш белән кияүне кыз мунчасына озаттылар ---.* Д.Булатова

**УЯУЛЫК** *и.* 1) Уяу, йокысыз булу хәле, уяу булган, йокламаган вакыт. *Кирәк йокыда, кирәк уяулыкта даим җәһәннәмне исеңдә тотмакың сине Хак Тәгаләгә тоташтырыр.* К.Насыйри. *Ул, йокы белән уяулык арасына чумып, үзе белгән бөтен кешеләрне уе аша үткәрә башлады.* А.Гыйләҗев

2) Сизгерлек, саклык. *Утырыш карары нигезендә бөтен оешмага уяулыкны көчәйтү бурычы куелды.* Г.Әпсәләмов. *Ә күктә тилгәннәр әйләнә, уяулыгыңны югалтсаң, бәпкәләреңне бик тиз чүпләп бетерәчәкләр.* Ф.Яруллин

# Ү

**ҮБЕШ** *и. урт. юн.* Бер-берсен үбү күренеше. *Үбеш арасында кайнар сулыш белән ул: – Кичерең мине... мин сөямен сәне... [диде].* Р.Батулла

**ҮБЕ́Ш-КОЧЫШ** *и.* Үбешү, кочаклашу һ.б. ярату, иркәләү билгеләре. *Үбеш-кочыш мәгъшукаларның йөрәкләренә төште.* М.Әмирханов

**ҮБЕШҮ** *ф. урт. юн.* 1) Бер-береңне үбү. *Гыйшык ләззәте белән ләззәтләнеп, егет вә кыз үбешеп, кочышып, берберсенә якын сарылдылар.* М.Акъегет. *Дуслар, бик күптән күрешми торган шикелле, үбешеп күрештеләр дә өйгә кереп киттеләр.* Ф.Әмирхан

2) *күч.* Җиңелчә бәрелешү (машиналар тур.). *Соң үзеңнең машинаң да, теге кызыл феррари белән үбешкәннән соң, автосервиста бер төн үткәрде бит.* Ф.Бәллүр

**Үбешә башлау** Үбешергә тотыну. *Тагы бер мизгелдән, Сергей Ивановичның фамилиясен да сорап белгәчтен, алар бер-берләренең аркаларын төятөя кочаклаша, үбешә үк башлаганнар иде инде.* Р.Мөхәммәдиев. *Алар тупыл янына җитеп, шунда үбешә дә башладылар.* Ф.Яхин

**Үбешеп алу** Тиз генә, әз генә үбешү. *Тегеләр үбешеп ала.* Р.Сәгъди. *Алар, үз ирләрен каршылагандай, чупы-чупы үбешеп алдылар.* Р.Батулла

**Үбешеп тору** Даими яки әледән-әле үбешү; әле, хәзер үбешү. *Гаражыгызда кем белән үбешеп тордың, ә?* Ә.Хәсәнов. *Өр-яңа костюм-чалбар кигән Газдал ишегалды уртасында Руфинә белән үбешеп тора иде!* Ф.Садриев

**Үбешеп чыгу** Рәттән барысы да үбешү

**ҮБҮ** *ф.* Ярату, иркәләү, ихтирам, буйсыну билгесе итеп, шулай ук очрашканда, саубуллашканда иреннәрне берәүнең иреннәренә, кулына, битенә яки предметка тидереп алу, куеп тору. *Сине үбәргә, аһ, кыялмадым мин. Калды тиле күңелем янган хәлендә. Мәүлам, ирештер морадка мине дә?!* Р.Гаташ. *Үтәмешгәрәй анасының чәчләреннән сыйпый, кулларын үбә.* М.Әмирханов

**Үбә башлау** Үбәргә тотыну. *Ул, тиз генә бала алдына чүгеп, битләреннән, күзләреннән үбә башлады.* Г.Әпсәләмов. *Янына килеп, Александрны төрле яклап кочаклый, үбә башлагач кына, ул моның төш түгел, өн икәнен аңышты.* Ф.Хуҗин

**Үбә бирү** Һаман үбү; бернәрсәгә карамастан үбү

**Үбеп алу** Бер мәртәбә үбү. *Фәләхне күреп алу белән аның йөзе кинәт балкып китте, һәм ул Фәләх янына машинага кереп утырды да ирен очы белән генә аны үбеп алды.* В.Нуруллин. *Луиза, йөрәксенеп, егетне үбеп алды.* А.Гыйләҗев

**Үбеп кую** Кисәк үбү. *Ул хәтта, малай уйнап бетергәч, аны кочып үбеп тә куйды.* Г.Әпсәләмов. *Бию ыгы-зыгысы арасында Дания мине үзенең буяулы иреннәре белән үбеп куя ---.* Ф.Яруллин

**Үбеп тору** Берникадәр вакыт яки әледән-әле үбү; еш үбү; әле, хәзер үбү. *Ислам үзенә тиешле чынаякны голт кына итеп әйләндереп куйды да икенче мизгелдә, ялт иттереп, Зифаны кочагына суырып алды һәм, чәчәк таҗына кунган бал кортына охшап, озак итеп, тәмле итеп, кызның иреннәреннән үбеп торды.* В.Имамов

**Үбеп чыгу** Һәммәсен берәм-берәм үбү. *Таһир аларның һәрберсен берәмләп-берәмләп үбеп чыгарга әзер.* А.Хәсәнов. *Гәүһәршад үзеннән-үзе шул кулларга тартылды, алмаш-тилмәш үбеп чыкты.* М.Әмирханов

**ҮБҮ́-КОЧУ** *ф.* Үбү һәм кочаклау; иркәләү. *Үпкән-кочкан – җилгә очкан.* Әйтем. *Борынгы кануннар канга сеңгән, күрәсең, авыр тормышлы крестьян гаиләсендә балаларны үбеп-кочып үстермиләр, аңа карап, күңелдәге ихтирам, ярату хисе ким булмый...* Р.Хәбибуллина

**ҮГӘЧ** *и.* Муенның алгы өлеше күкрәккә тоташкан урын (атларда). *[Атларның] Үгәченә камыт сукканнарын, яралыларны дәваларга, дагалары бушаганын я сынганнарын калдырырга һәм дагалатырга тиеш мин.* А.Расих

**ҮГЕЗ** *и.* **1.** 1) Мөгезле эре терлекнең иркәге. *Шунда күреп кайттым: болгарлар җирне үгезгә җиккән сабан белән сөрәләр икән.* М.Галәү. *Аның ике сыеры, бер кышлау үгезе, сигез сарыгы, тагын әллә никадәр мал-туары бар.* Ф.Яхин

2) Партояклы эре хайваннарның иркәге. *--- аланның теге як читендә, дөньяларын онытып, ике поши үгезе сөзешеп тора, ә бер ана поши, аларга гел дә игътибар итмичә, алан буендагы яшь усак яфракларын ашый иде.* В.Нуруллин. *Бигрәк тә күлнең аръягында беренчелек өчен сөзешкән болан үгезләрен ис-акыллары китеп күзәттеләр.* Р.Сәгъди. *Югыйсә бу сөякләрнең я мамонт, я берәр бронтозавр үгезенеке булуына шик томмый иде.* А.Тимергалин

3) *күч. мыск.* Ир-ат. *– Син үгезгә ышанган мин юләр, – диде [ул Харискa].* Н.Яһудин

**2.** *с. мәгъ.* Иркәк җенестәге (партояклы хайваннар тур.). *Украсына чыдый алмаган кысыр бияләр, үгез башмаклар, койрыкларын чәнчеп, ялан туздырып чабып киләләр дә күлгә төшәләр.* Г.Ибраһимов. *Атасы төсле шомырт кара, ак башлы, томрап торган үгез бозау китергән.* Т.Гыйззәт

◊ **Үгез алдында кызыл чүпрәк белән җилпү** Котырту; ачуны чыгару. *Алар өчен милиционерларның пистолет болгап кычкыруы – үгез алдында кызыл чүпрәк җилпү генә: кызып кына китәчәкләр.* З.Мурсиев. **Үгез астыннан бозау эзләү** Булмастайны эзләү, таптыру. **Үгез күзе хәтле** Бик кечкенә. *Бер-берсенә ырып кертеп койган такталарны караштырып чыккач, ул бер урында, аста, үгез күзе хәтле генә йомры тишек күреп алды һәм, калак сөякләрен шыгырдатып, шунда иелде.* А.Гыйләҗев. *– Шәп тә кеше соң Мансур Гаделевич, – дип, ашыкмый гына, түш кесәсеннән үгез күзе кадәр генә бәләкәй көзгесен чыгарып, каш-күзен төзәтергә тотына.* Р.Мулланурова. **Үгезе үкерү** *к.* **бүресе улау**. **Үгез кебек (төсле, шикелле)** 1) Калын бәдәнле һәм көчле, таза (кеше тур.). *Ире Галигә көн-төн сыкрана: – Үгез кебек угылың бар... Аны мәдрәсәгә йибәрәсең дә, мин монда эт көнендә йөрим... – ди.* Г.Ибраһимов. *Аширов – нәселле үгез шикелле сау-таза, һәм җанын пинжәк кесәсендәге дүрткә бөкләнгән, монда,*

*Ступинода кулга төшергән үпкә туберкулёзы белән авыруы турындагы медицина белешмәсе җылыта иде.* Ә.Мушинский; 2) Зур һәм егәрле (җансыз әйберләр тур.). *Аркылыга да, буйга да казылып беткән киң мәйдан уртасында ике үгез кебек ике бульдозер кара-каршы тора ---.* Г.Әпсәләмов; 3) Бик кире, үзсүзле; 4) Бик күп, зур көч куеп. *Уртак файдага үгез кебек эшләячәкмен.* М.Галәү. *Сөйләп торган була, ичмаса, ир дисәң – хәтере калыр, әнә күрше Вәлидән үрнәк ал: үгез шикелле эшли, акчаны да умырып ала.* Ф.Имамов. **Үгезне мөгезеннән алу** Эшнең иң мөһим, кирәкле урыныннан башлау, тиз эш итә башлау. *– Сез молодец! – диде [егет]. – Үгезне мөгезеннән алдыгыз! Минем батя аны-моны уйларга да өлгерә алмый калды – сеңелкәшне эләктереп тә куйдыгыз, ә?* К.Тимбикова. **Үгезне мөгезеннән эләктерү** *к.* **үгезне мөгезеннән алу**. *– Я, ни дип юмаларга җыенасыз мине? – дип, сөйләшүне үгезнең мөгезеннән эләктереп башлады Ильяс Алкин.* Р.Мөхәммәдиев. *Директор урынбасары, кабинетка килеп керү белән, сүзен шунда ук үгезнең мөгезеннән эләктереп башлады ---.* И.Нәбиуллина. **Үгезнең мөгезеннән тоту** *к.* **үгезне мөгезеннән алу.** *Үгезнең мөгезеннән тотып сөйләшәм: «Фәлән Фәләнович, – минәйтәм, – без, Насретдинов белән (Мөнир райкомолның беренче секретаре, соңыннан съезд делегаты булды, озак еллар партия-совет оешмаларында эшләде) хәзер генә аэродромда булып кайттык».* Г.Гомәр. **Үгез сөзгән** *эвф.* Кияүгә чыккан (кыз тур.)

**ҮГЕЗБӘБӘК** *и.* Ботак, кәүсә сынган урыннан үсеп чыккан бәбәк; *русчасы:* **волчок**

**ҮГЕ́ЗБОЗАУ** 1) *астр.* Бик якты Әлдәбәран йолдызын һәм ике төрле йолдызлар тупланмасын эченә алган йолдызлык

2) Йолдызнамәдәге унике йолдызлыкның берсе (21 апрельдән 21 майга кадәр) һәм шул вакытта туган кеше. *Нинди җиңел сөйләшү сеңлең белән! Бизмән билгесенең телен мин беләм... Кучкар белән Үгезбозау очраша Гел сөзешә – я, нишлим синең белән?!* Р.Гаташ. *Илдар Үгезбозау йолдызлыгында туган бит ул...* Ф.Җамалетдинова

**ҮГЕ́З БОРЫНЫ** *и. диал. к.* **үгез күзе**. *Башта узган елдан сакланып калган чикләвекләрне җыйдык, аннары төрле үләннәр: балтырган яфрагы, казаяк, какы, кузгалак, үгез борыны, кыр суганы табып, биштәрләргә тутырдык.* И.Диндаров

**ҮГЕЗКҮЗ** *и.* Акайган зур күзле кеше. *Бу үгезкүзгә ни кирәк тагын?!*

**ҮГЕ́З КҮЗЕ** *и. бот.* Оешмачәчәкләләр семьялыгыннан сары чәчәкле, озын сабаклы күпьеллык үсемлек; *русчасы:* **арника**. *Балан һәм үгез күзен саграк кулланырга, чөнки алар канны куерту сыйфатына ия.* Заман сулышы

**ҮГЕЗЛЕК** *и.* 1) Үгезгә хас сыйфатлар. *Акмаңгай баштарак Хәмиттән качып китәргә тырыша иде, әмма тора-бара аның йөрәгендә үгезлек ярсуы кузгала башлады.* Ф.Яруллин

2) Билгеле бер сандагы үгезгә җитәрлек. *Мин 91–92 нче елларда гына да бер утыз үгезлек акчаны яндырдым: иске акчалар белән 18 мең ярым.* Безнең гәҗит

3) *куч.* Кешеләрне этеп-төртеп йөрү, аяусыз кылану гадәте. *Үз үгезлеген күрсәтү*

**ҮГЕ́З ТЕЛЕ** *и. бот.* Кыярчалар семьялыгыннан ланцетсыман яфраклы, күк, зәңгәр яки сары таҗлы бер яисә күпьеллык чүп үлән; *русчасы:* **воловик**

**ҮГЕТ** *и.* Кемне дә булса яхшы эшкә өндәп, начар, ярамаган гадәтләрне ташларга чакырып әйтелгән сүзләр, нәсыйхәт. *[Әниеңне] Онытыр хәлем юк: утырта, сөйләтә, ашата-эчертә, үгет бирә, күңелемне ала, кайгыларымны тарата иде.* Г.Исхакый. *Мондыйлар бездә бик сирәк, Имгәк Юныска әзрәк үгет кирәк. Тәрбиялик аны, кеше булсын, Сознательный, яхшы эшче булсын!* Г.Афзал

◊ **Үгет керү** Үгетне тотып эш итү. *Үгет кермәс кешегә бирмә үгет, Өйрәтмә син мине, дип сүгәр ул эт.* Г.Утыз Имәни. *Гафур аның белән сүз көрәштереп тормады: тимергә – кадак, игелексезгә үгет кермәни?* З.Мурсиев. **Үгет сату** Кирәкмәгәнгә өйрәтү, үгетләү. *Мин аңа киңәш йөзеннән генә әйткән идем, үгет сатып түгел.* Н.Исәнбәт. **Үгет уку** Үгетләү. *Дәвалау берничә көн дәвам итте, һәм Вәгъдәгөл берничә көн Солтанъярга үгет укыды.* З.Мурсиев

**ҮГЕТ-ВӘГАЗЬ** *җый. и.* Үгет һәм вәгазьләр. *Хәер, арабызда бай кешеләр булган очракта да, без барыбер аларның үгет-вәгазьләрен тыңламаган булыр идек, барыбер шулай таралышып беткән булыр идек.* М.Галәү

**ҮГЕ́Т ИТҮ** *ф.* Үгетләү. *Чәчәк аз, кызыл шәкыйк гөлләр юк, дип Ни мәгънә умартаны бозу белән?! Корт ана баса илен, үгет итә.* Ш.Бабич

**ҮГЕТ-КИҢӘШ** *җый. и.* Үгет һәм киңәшләр. *Сафа төрле яктан яуган үгет-киңәшкә каршы килә алмады.* М.Галәү

**ҮГЕ́Т КЫЛУ** *ф. иск.* Үгетләү. *Анам да сизенә булса кирәк – чакырып үгет кылды; мин җыладым, көчләсәгез, гәүдәмне Алтын күлдән эзләрсез, дидем...* Г.Ибраһимов

**ҮГЕТЛӘ́Ү** *ф.* 1) Кемне дә булса яхшы эшкә өндәү, начар, ярамаган гадәтләрне ташларга чакыру. *Мөсафир инде шәкертен үгетләми, бары тик үзалдына сөйләгәндәй фикер чәчә иде.* Р.Батулла

2) Чакыру, кыстау. *Мөдир Сәйдәшевне гаризасын кире алырга үгетли, администрация исеменнән гафу үтенә, чөнки автобусны башка шофёрга тапшыруны ялгыш булган дип саный.* А.Тимергалин

3) *сөйл.* Димләү, риза булырга күндерергә тырышу. *Яучыны тегеләйболай юаткалап чыгарып җибәрәләр дә, ул киткәч тә, Мәрьямне үгетләргә керешәләр.* Н.Яһудин

**Үгетләп алу** Бераз үгетләү. *Әни кайчакларда апамны үгетләп тә ала.* Ф.Төхбәтуллин

**Үгетләп җибәрү** Бераз үгетләү. *Өркетеп, куркытып яки үгетләп җибәрсә дә – файдага, күрсә, шаһитлык итсә, бәлки, уйланырлар, явыз ниятләреннән баш тартырлар.* Ә.Әминев

**Үгетләп җиткерү** Ышандырырлык, күндерерлек итеп үгетләү. **–** *Корбан гаетен үткәрик, шуннан ары җибәрербез инде, – дип, яшь кияүне көч-хәл белән үгетләп җиткерделәр.* В.Имамов

**Үгетләп калу** Вакытында, форсаттан файдаланып үгетләү. *Эшен ташлап, шабашкага китмәкче иде, көчкә үгетләп калдым.* Г.Каюмов

**Үгетләп килү** Күптәннән бирле, эзлекле рәвештә үгетләү. *– Озакламый яңа йортка күченәбез, әтиеңә әйберкара ташырга булышырсың, – дип үгетләп килде үги әнисе.* М.Маликова. *Ләкин, күргәнебезчә, боларның барысына да гүзәл һәм акыллы Ширин аркасында ирешелгән, чөнки хис белән мавыгып киткән Хөсрәүне ул үгетләп килә.* Н.Хисамов

**Үгетләп тору** Даими яки әледән-әле үгетләү; әле, хәзер үгетләү. *Ире иңенә курткасын салып чыгып киткәч тә, Зилә аның артыннан бераз үгетләп торды әле.* Г.Гыйльманов. *Юк, моны*

*үгетләп торырга кирәкми, акча бирәсе дә түгел, бу үзе шатланып риза булырга тиеш, дип уйлады ул.* З.Мурсиев

**Үгетли башлау** Үгетләргә тотыну. *Мәйсәрә Мөхәммәдтән алган җавапны Хәдичәгә кайтарды һәм егетне үзенә дәштереп алырга үгетли башлады.* Ф.Яхин. *Эш урыныннан ял йортына юллама биргәч, Вәлиҗан хатынын үгетли башлады ---.* Р.Габделхакова

**Үгетли тору** Билгеле бер вакыт үгетләү. *Үгетли торгач, Мөслах карт улын өйне барып карарга тәки күндерде.* Ф.Яруллин. *Әти-әни һаман: «Аның турында бүтән уйлыйсы булма, бер хатаны ике тапкыр кабатламыйлар», – дип үгетли торды.* Сөембикә

**ҮГЕТЛЕ** *с.* Үгет, нәсыйхәт белән сугарылган. *Ул кинәт җитдиләнде һәм йомшак, үгетле тавыш илә иренә дәште: – Ханкай, җанкай, – диде.* Р.Батулла. *Үзебезнең милли каналлардагы тапшыруларда да ак күкрәгән ачып салган ак яулыклы мөслимәләребезнең без дәһриләргә дин-шәригать хакында үгетле вәгазь укып утырганнарын күрергә туры килә.* Мәдәни җомга

**ҮГЕТ-НӘСЫЙХӘТ** *җый. и.* Һәртөрле үгет һәм нәсыйхәт. *Бүген, шушы яшемә җиткәч, милләтем дип әйтергә, милләтемә үгет-нәсыйхәтемне бирергә хакым бардыр дип беләм!* Ф.Яхин. *Ачуын басып, хәзер инде ул үгет-нәсыйхәт бирергә керешә.* З.Мурсиев. *Олысның могтәбәр кешеләре Елмаймас мирза Исмәгыйльгә бу эшләре өчен үгет-нәсыйхәт биреп тә карадылар, тик ул аларны түгел, Борнаш сәет сүзен дә колагына элмәде.* Р.Батулла

◊ **Үгет-нәсыйхәт кылу** Үгет-нәсыйхәт бирү. *Фатыйма абыстай: «Балам, тырышып кына укы, мулла булырсың!» – дип үгет-нәсыйхәт кыла ---.* З.Һади. **Үгет-нәсыйхәт уку** Үгет-нәсыйхәт белән җитди итеп киңәш сүзләре әйтү. *Белешмә җыйдырып, үгет-нәсыйхәт укып, йөзеңне кызартып үзәккә үтәләр.* М.Маликова. *Әхмәтҗанга үгет-нәсыйхәт укуга бер сәбәп булды.* Т.Гарипова

**ҮГЕ́Т-НӘСЫЙХӘТЛЕ** *с.* 1) Үгет-нәсыйхәт сүзләре катнаштырып сөйләнгән. *Үгет-нәсыйхәтле әңгәмә*

2) Үгетләү рәвешендә язылган. *Үгет-нәсыйхәтле хикәя*

**ҮГЕ́Т-НӘСЫЙХӘТСЕЗ** *рәв.* Үгет-нәсыйхәт бирергә тырышмыйча, үгет-нәсыйхәттән башка. *Үгет-нәсыйхәтсез булмый инде ул тәрбия*

**ҮГЕТСЕЗ** *рәв.* Үгетләмичә, кыстамыйча гына. *Ике укытучы өчкә бүленә алмый бит инде, балалар белән өченче баржада кайтуны Марвадан үтенделәр. Әлбәттә, һич үгетсез риза Марва.* Ә.Баян

**ҮГЕТЧЕ** *и.* 1) Үгетләүче, үгет-нәсыйхәт бирүче. *Шундый ук ысул белән Бәхтияр Канкаев Красноуфимск каласына да үгетчеләр җибәрә.* В.Имамов

2) Агитатор. *Ырынбурда «Эшче», «Туплан» гәзитләре хезмәткәре, 1918 елда «Туплан» демократик җәмгыятенә нигез салучыларның берсе, 1919 елда Беренче Армиянең мөселман труппасы артисты, аннары хәрбиләр арасында үгетче – революция аңа яңадан-яңа вазифаларны йөкләп кенә тора.* Т.Әйди

**ҮГЕТЧЕЛЕК** *и.* Вәгазь сөйләргә, үгетләргә, өйрәтергә ярату сыйфаты. *Әмма бу – акыл сату, ялыктыргыч үгетчелек, дип уйларга ярамый.* М.Гайнетдин

**ҮГИ** *с.* **1.** 1) Бер гаиләгә караган, әмма шул нәселдән булмаган, чит канлы. *Үги бала үз булмый, иске күлмәк бүз булмый.* Мәкаль. *Шул үги әби инде әтинең булдыклылыгын белә икән, бик кайтартырга тырышкан, әнигә әллә нинди егетләр исеменнән дип хатлар китерткән.* Г.Исхакый

2) *күч.* Чит, ят; кагылган, сугылган; тиешле бәясен алмаган. *Вахид тегеятлыкны биргән нәрсә, моның тыныч күңеленә теге үги дошман фикерне суккан нәрсә – шул күзләр икәнен бердән хис итте.* Г.Исхакый

**2.** *и. мәгъ.* Үги (*1 мәгъ.*) кеше. *– Алайса без икебез дә рәхимсез язмышның бәхетсез үгиләре икәнбез, – ди.* С.Сабиров. *Әйтерсең лә алар үз балаларыбыз түгел, ә үгиләр.* Р.Миңнуллин

**ҮГИ АНА́ ЯФРАГЫ** *и. бот.* Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан сары чәчәкле, яфракларының асты аксыл һәм кытыршы булган үлән үсемлек; *русчасы:* **мать-и-мачеха**. *Йорт янындагы бакчада алмагачлар арасына тартылган кер бавында очып китәргә җыенган дәү аккош кебек ак күлмәк җилферди, бакча як тәрәзә төбендә зәп-зәңгәр вазада яшькелт үги ана яфраклары балкып утыра иде.* А.Гыйләҗев. *Данияр, аяк астына иелеп, үги ана яфрагы өзеп алды да, мине үртәп, борын төбендә җилпәзә итеп селкеп алды.* А.Әхмәтгалиева

**ҮГИ́ ИТҮ** *ф. к.* **үгисетү**. *Кесәңә акча тутырып чыкмасаң, шәһәр сине үги итә.* М.Юныс. *Ялкауларны бәхет үги итә, Койрыгын да хәтта тоттырмый.* Н.Әхмәдиев. *Нигә син үз балаларыңны болай үги итәсең, рәнҗетәсең икән?* Ф.Яруллин

**ҮГИ́ КЫЛУ** *к.* **үги күрү**. *Борынгылар: «Кеше иләндә солтан булганчы, үз илеңдә олтан бул», — дисәләр дә, ни эшлик, анамыз Сары Арканың киң даласы безне үги кылды!* Г.Ибраһимов

**ҮГИЛЕК** *и.* Үги булу, үксезлек. *Нәселе бер булмаса да, үгилекләре бер ич инде.* Г.Исхакый. *Эченнән кайгырып уйлады: «Менә бит, утын агачлары кебек нәрсәләр! Шулай да киң дөньяда йөзәләр. Безгә генә үгилек төште, күрәсең!» – диде [ул].* Г.Ибраһимов

**ҮГИСЕНҮ** *ф.* 1) Үзен үги итеп хис итү

2) Кимсенү, үзен кыерсытылган дип исәпләү

**Үгисенеп калу** Нindидер эш-сәбәптән соң үгисенү. *Авыл бушап, үгисенеп калгандай булды.* Шәһри Казан

**ҮГИСЕТҮ** *ф.* 1) Чит итү, якын күрмәү; кагу. *Ватан аларны үгисетмәсен, без дә шәфкать, мәрхәмәт күрсәтик аларга!* Т.Әйди

2) *күч.* Лаек дип санамау, санга сукмау. *Бу каләмдәшләребезгә читсенеп, үгисетеп карау әдәбиятыбызны тарайту булыр иде.* Р.Фәйзуллин

**Үгисетә башлау** Үгисетергә тотыну. *Монысы да мактауга лаек, югыйсә соңгы елларда авыл кешесен бөтенләй үгисетә башлаганнар иде.* Безнең Чирмешән

**Үгисетеп килү** Күптәннән эзлекле рәвештә үгисетү. *Махсус тәнкыйтьнең булмавыннан файдаланып, балалар әдәбиятын үгисетеп килделәр.* Р.Миңнуллин

**Үгисетеп тору** Даими яки әледән-әле үгисетү

**ҮҖӘТ** *с.* **1.** Үзе теләгәнчә эшли торган, үзсүзле, сүзен бирмәс. *Юныс мирза үҗәт кеше иде, ишекне япсалар – тәрәзәдән, тәрәзәне япсалар, ишектән керә торганнардан.* М.Әмирханов // Тыңламаучан, кире. *Шундый ягымлы, уңган ата-анадан нигә киребеткән, үҗәт, чамасыз шук балалар туа икән?* А.Гыйләҗев

**2.** *и. мәгъ.* Үзсүзле, сүзен бирмәс кеше. *Үҗәт, күзен бирсә дә, сүзен бирмәс.* Мәкаль

**ҮҖӘТЛӘНҮ** *ф.* 1) Киреләнү, берәр нәрсәгә каршы килеп эш итү. *Директор иренеп кенә башын күтәрде дә, барыбер буш кайтарып җибәрәм бит инде, нигә бу тикле үҗәтләнәсең, дигәнне аңлата торган итеп елмаеп куйды.*

В.Нуруллин. *Әмма тиз генә бирешергә гадәтләнмәгән малай үҗәтләнеп чокчынуын дәвам итте.* А.Гыймадиев

2) Үз дигәненчә итәргә тырышу; үз дигәнен булдырырга тырышу. *Үҗәтләнеп, ныгытып, ярсып эшли ул.* А.Гыйләҗев

**Үҗәтләнә башлау** Үҗәтләнергә тотыну. *Барыбер мин сине кулга төшерәм, дим, үҗәтләнә башладым.* Д.Каюмова

**Үҗәтләнә бирү** Бернигә карамый үҗәтләнү. *– Әнием, җан кисәгем, тыңла инде сүземне! – диде Равил, һаман үҗәтләнә биреп.* В.Нуруллин. *Ләкин Мотаһир да үҗәтләнә бирә ---.* Р.Кәрами

**Үҗәтләнә төшү** Бераз үҗәтләнү; тагын да үҗәтләнү. *Ләкин Гөлчирә бер башланган ул татлы уенны ташлый алмады гына түгел, Әсфанның ташлау ниятен сизеп, ул тагын да үчекләнә, үҗәтләнә төшеп тотынды.* Ф.Хөсни. *Әмма Хәмит аның саен үҗәтләнә төште: шаяртып маңгаена чиертүләр генә тәэсир итмәгәч, каты-каты итеп суккалаудан да тайчанмады.* Ф.Яруллин

**Үҗәтләнеп алу** Бераз, берара үҗәтләнү. *– Ачыклары да бардыр әле, – дип үҗәтләнеп алды кунак статуслы ата.* Җ.Юныс

**Үҗәтләнеп йөрү** Берара үҗәтләнү; әле үҗәтләнү. *Берәүләр, бик озак үҗәтләнеп йөргәч, квартир алу бәхетенә иреште, икенчеләре ярык тагарак янында утырып калды.* Туган як

**Үҗәтләнеп китү** Кинәт үҗәтләнү. *Этнослар турында бәхәс барганда, тәмам үҗәтләнеп китә торган иде.* М.Хәбибуллин

**Үҗәтләнеп тору** Даими үҗәтләнү; әле, хәзер үҗәтләнү. *Бик үҗәтләнеп торсаң, абруйлы вазифаңнан колак кагуың да бар югыйсә!* Т.Әйди

**ҮҖӘТЛӘШҮ** *ф. ялг. к.* **үҗәтләнү**. Үҗәтлек, кирелек, үзсүзлелек күрсәтү. *Мин үземнең наданлыгымнан шул чакта бик үртәлеп, оятымнан үҗәтләшеп, болай дигән идем: «Лорканы мин белеп кенә калмаячакмын, күреп торырсың, аның туган җиренә – Испаниягә дә барачакмын!»* М.Галиев. *Математикларча төгәл, тиз фикерләү, заманча яшәү, тормышны өйрәнү, үҗәтләшеп эшләү, практик гамәлләр кылу аны шул вакытта ук XXI гасырның көчле шәхесенә әверелдерде.* Р.Вәлиев

**ҮҖӘТЛЕК** *и.* Үзсүзлелек; кирелек, тискәрелек. *Наилә күңеленең шашынганын, кан тамырларында кирелек, үҗәтлек, усаллык дулкыны ташыганын тойды ---.* А.Гыйләҗев. *Тик теге яктагы кешенең үҗәтлеге чиктән ашкан иде, ахрысы, телефон, SMS килгәнен хәбәр итеп, сандугачтай сайрап куйды.* А.Әхмәтгалиева

**ҮЗ** (үзем, үзең, үзе, үзебез, үзегез, үзләре) *а.* 1) Сөйләмнең субъекты булган зат. *Бәхетсезлегенә каршы, бу вакытта хәзрәтнең хатеренә яңадан көтелмәгән бер нәрсә килмәсенме: ул, үз өстендә чалма-чапан булмагач, аның голәма сыйныфыннан икәнен халык белмәячәк тә садака өләшкәндә бирми китәчәк икәнен уйлап алды.* Ф.Әмирхан. *Анысын без үзебез беләбез.* Г.Исхакый

2) Сүз барган затка, предметка караган. *Үз халкын сөймәгән, башка халыкны да сөймәс.* Мәкаль. *Шул сүзләрне әйтеп, буе матча чаклы Капкорсак патша идән буенча бер атлаган иде, идән сыгылды, ди, икенче атлаган иде, үз аягына үзе абынып егылды, ди.* А.Алиш

3) Сүз барган зат булдырган, тапкан, иҗат иткән; аның шәхси милкенә караган. *Чөнки ул – үз милкен үзе урлаучы, иң соңгы кабахәт кеше!* А.Алиш. *Чөнки Касыймның Япуниядә үз байлыгын калдырып китәрдәй якын туганы юк.* В.Имамов. *Кулына алгач, әбекәй үз гөленә озак кына карап торды, аннары неп-нечкә, үтәкүренмәле бармаклары белән аның яфракларын, чәчәкләрен сыйпап алды, сак кына күкрәгенә кысты...* Г.Гыйльманов

4) Сүз барган әйбергә билгеләнгән; аңа туры килгән; аңа гына хас булган. *Дөньяның үз җае бар шул, һәр чиләкнең үз капкачы, дигәндәй, алар бербереннән башка яши алырлар идеме?* Ф.Яхин. *Әмма өстәл янында бер дә сиздермим, һәрнәрсәнең үз вакыты бар.* Р.Рахман

5) Сүз барган затка туган, кардәш; якын, иптәш тиешле. *Үз анаң – бавырсак, үги анаң – сарымсак.* Мәкаль. *Әй Ходаем, ник мине үз баламнан мыскыл иттерәсең!* Ф.Әмирхан

◊ **Үз авызыннан ишетү** Кеше аша түгел, шунда үзе булып, сөйләүчене күреп ишетү, аның белән турыдан-туры сөйләшү. *Мәгәр менә хәзер синең үз авызыңнан ишетәсем килә.* В.Имамов. **Үз акылында** Сәламәт акыллы, психик яктан нормаль. *Мин хәтта аның үз акылында булуына шикләнеп, акрын гына читкә тайпылдым.* З.Мәхмүди. *– Кызым да үз акылында иде, мин аны камил акыллы килеш тимерче оста Әхмәткә китереп бирдем, – диде илче һәм тиз-тиз чукынып алды.* М.Хәбибуллин. **Үз акылы үзендә** Аңлый алырлык, үз эшенә җавап бирерлек; җитлеккән. *Бала буй үстергән, үз акылы үзендә, син өйрәтеп кенә аннан әллә кем чыкмас!* А.Гыйләҗев. *Инде Җамал апаңа акыл кертеп булмас, үз акылы үзендә, үсмер чакта ук тәртә арасыннан чыгып китте.* Ф.Сафин. **Үз арбасына утырту** Үзенә, фикеренә ышандыру, үзенә авыштыру, ияртү; үзенчә итү. --- *милләтне һәрберсе үз арбасына утыртырга тели.* Татарстан яшьләре. **Үз аршыны белән үлчәү** Шәхси белем, күзаллау нигезендә субъектив фикер йөртү. *Һәрнәрсәне, баланың һәр адымын үз аршының белән үлчәмә.* А.Гыйләҗев. *Хәер, монысына без үзебез дә гаепле, чөнки --- дөньядагы бөтен нәрсәне үз аршыныбыз белән генә үлчәп сөрсеп ятканбыз...* А.Тимергалин. **Үз аягы белән** 1) Кеше ярдәменнән башка. *– Ну, асыл кошлар, үз аягыгыз белән килеп эләктегез, – диде колхозчы Вәли.* А.Алиш. *– И ирем, ничек күтәрә алдың аны, әллә үз аягы белән килдеме? – дип, юха тел белән сөйли икән бу.* Ф.Яхин; 2) Үзе теләп, мәҗбүр итмичә, чакырмыйча. *– Безгә ризык та үз аягы белән килде, бу Кәҗә белән Сарыкны боткадан соң тотып ашарбыз, – ди.* Әкият. *Үз аягың белән барасыңмы, әллә милиция машинасы чакыртыйммы?* И.Юзеев. **Үз башына** 1) Үзлектән; мөстәкыйль рәвештә. *Дөрес, безгә ярдәм кылучы, арка таянычы булырлык хөкүмәтебез юк, ләкин халык теләсә, үз башына бик күп эшләр эшләргә булдырадыр.* Г.Буби; 2) Аерым, бәйсез, мөстәкыйль. *Ләкин үз алдына, үз башына дөнья көтеп, Алатауның туйлары эчендә кайнаган Мәрхәбә әле һаман канәгатьсез иде ---.* Г.Ибраһимов. *Төркестан үз башына яшәргә тотынмады.* Г.Исхакый. *Кушымча (аффикс) – һәрвакыт тамырның азагына кушылып, аңа ияртеп әйтелә торган, үз башына аерым торганда мәгънәсе булмаган кисәк ---.* Г.Алпаров; 3) Үзенә зыянга. *Кайтса, үз башына. Аны тотып асардай элмәк әзерләр.* В.Имамов. **Үз башына үзе җитү** Үз үлемендә үзе гаепле булу. *Шул чамасыз күп эчүе аркасында үз башына үзе җитте дә: кышкы салкында исерек килеш районнан кайтышлый, чалу урында чанасыннан егылып, катып үлде мәрхүм.* В.Нуруллин. **Үз башыннан чыгару** 1) Үзе

уйлап эшләү. *Ә бит ул әлеге поэманы кайдандыр күчереп түгел, үз башыннан чыгарып язган!* В.Нуруллин; 2) Нигезсез, дәлилсез, булмаганны үзеннән өстәп сөйләү. *Шуның артыннан үз башыннан чыгарып: – Минемчә, бу елга шулай калдырырга кирәк. --- Бик кызулап җибәреп, халыкны дулатып җибәрмик димен ---, – дип сүзен бетерде.* Г.Исхакый. **Үз башыннан кичерү** Үз тәҗрибәсендә сынау, үзе күреп, газабын яки рәхәтен тату. *Бер нәрсәдән икенчегә сикереп, аннан тагы кире кайтып, үзләренең башыннан кичкәннәрне тәртипсез, ашыгыч сөйләп үттеләр.* Г.Ибраһимов. **Үз башыннан үтү** *к.* **үз башыннан кичерү**. *– Сез мине оныткансыз инде, мин – сездән яшь калган улыгыз Әхмәт, хафаланмагыз, хәзер үз башыгыздан үткән эшләрне белерсез, – дип, кулларында тоткан киемнәрне кияргә тәкъдим итте.* Ф.Әмирхан. **Үз башына төшү** Башкалар күргән мәшәкатьләр, газаплар һ.б.ш.ны үзенә кичерергә туры килү. *– Үз башына төшкәч, барысын да булдырыр әле, юк өчен кайгырмагыз, – диде Гөлшәһидә.* Г.Әпсәләмов. *– Әнә шул яманлык үз башына төшмәсен, – дияр иде ул.* З.Мурсиев. **Үз белдеге белән** 1) Үзенчә, үзе аңлаганча, үзе белгән кадәренчә. *Тик бу синең эссе ташлы мунча эчең, яисә туган-үскән авылың түгел, үз белдегең белән генә бернәрсә дә кыла алмыйсың!* З.Зәйнуллин; 2) Рөхсәтсез, киңәшсез; эшне белер-белмәс. *Инде менә Шәмсинең улы Талибны да, үз белдеге белән акча суга, диләр.* В.Имамов. *Аннары бит, мин үз белдегем белән түгел, директор рөхсәте белән калдым.* Х.Сарьян; 3) Әрсезләнеп, үзенә кирәк булганча. *Үз белдегең белән өлкәннәрдән узма!* К.Кәримов. **Үз бер тиене (бер) тиен** *к.* **үз тугызы тугыз**. *Җанкисәгем, синең белән сөйләштең ни дә, сөйләшмәдең ни: синең һаман үз бер тиенең бер тиен.* А.Шамов. **Үз бизмәне белән үлчәү** *к.* **үз аршыны белән үлчәү**. *[Наилә:] Үз бизмәнең белән генә үлчәмә. Кызларны аңларга тырыш.* А.Гыйләҗев. **Үз вакытында** 1) Тиешле вакытта. *Ата-анага үз вакытында кайтарылмаган бурыч, үтәлмәгән вәгъдәләр баланы түбәнсетә.* А.Гыйләҗев; 2) Заманында; элек. *Үз вакытында илнең төрле театрларында да менә шундый әсәрләре киң яңгыраш тапты.* А.Әхмәдуллин. **Үз дигәне** 1) Яраткан, күңел кабул иткән кеше. *Капка гына төбе – карама агач, Кәүсәсендә – тимгел каралар. Үз дигәнем килеп карамагач, Ят куллардан кемнәр аралар?..* К.Булатова; 2) Теләге, максаты. *Тырышып кына үз дигәнеңә ирешеп булса, иң элек мин ирешкән булыр идем аңа, Мидхәт.* В.Нуруллин. *Аның күз карашында, турсайган иреннәрендә, керпе сыман кабарынган бөтен торышында ниндидер үзсүзлелек, үз дигәнен булдырырга ашкыну бар иде.* Г.Әпсәләмов. **Үз дигәнендә тору** Үз фикереннән, карашыннан аз гына да чигенмәү; үҗәт булу. *Җиһанша бабай үз дигәнендә нык торучан, үзсүзле кире картлардан иде.* Г.Ибраһимов. **Үз җилкәсендә тату** Газапларны, авырлыкларны үзе кичерү. *Ул анасы Сабираның бик авыр холыклы икәнен кырык еллык гомерендә үз җилкәсендә күп татыды.* Г.Ибраһимов. *Боларның һәммәсен Гариф үз җилкәсендә татып белде инде.* М.Галәү. **Үз ирке белән** Үзе теләп. *Булмаса, дим, үз иркең белән Себергә китмәс идең, дим.* Г.Ибраһимов. *--- мин бу вазифадан үз иркем белән ваз кичәм.* А.Хәмзин. **Үз иркенә кую** Берәр эшне теләгәнчә, белгәнчә эшләргә мөмкинлек бирү; мәҗбүр итмәү. *Үсеп җиткәч тә, кайсы тирәккә кунып сайрауны аның үз иркенә куям... Н.Сәйяр.* **Үз ихтыяры белән** *к.* **үз ирке белән**. *Кыскасы, әгәр дә мәгәр атаң малыннан үз ихтыярың белән баш тартсаң, сиңа җил-яңгыр кагылмас.* А.Гыйләҗев. *Ләкин бәгъзе берәүләрнең сөйләвенә караганда, хан кызы бу зинданга үз ихтыяры белән ябылган, имеш ---.* Г.Рәхим. **Үз ихтыярына кую** *к.* **үз иркенә кую**. *Мин кайтканчы үз авылыгызда, әниең янында яшәп торсаң да ярый, дип, мәсьәләне Сәкинәнең үз ихтыярына куйган идем.* В.Нуруллин. **Үз итү** Якын күрү; туган итү; яхшы мөнәсәбәттә булу. *Керосинга килүче хатыннар, бик үз итеп: «Котбый абзый!» – дип эндәшәләр аңа.* Ф.Хөсни. *Танып алуга ук киң итеп елмаеп җибәрде, үз итеп аркамнан сөйде, аннары түргә дәште, артсыз урындыкның читенә генә утырып, дога кылды...* Г.Гыйльманов. **Үз кабыгына бикләнү** Башкалар белән аралашмау, башкалардан читләшеп яшәү. *Ул Яшке дә бик аз сүзле, үз кабыгына бикләнгәнрәк кеше бугай инде.* В.Имамов. *Хәер, соңгы вакытта ул үзенең бу халәтенә, үз кабыгына бикләнеп яшәүгә күнегә башлады.* Р.Кәрами. **Үз кабыгына йомылу** *к.* **үз кабыгына бикләнү.** *Татар үз кабыгына йомылып яшәгән, аралашмаган, шулай итеп үз-үзен саклап калган.* Р.Вәлиев. **Үз казанында кайнау** Аралашмыйча, үзенә генә кагылган тар мәнфәгатьләр белән яшәү. *Хәзер башкача: хәзер һәркем үз казанында гына кайный, кешегә керми, чыкмый, бар тормышы серле йомгак, һәр сүзен сайлап кына, теш арасыннан гына чыгара.* К.Кара. **Үз калыбына кайту** Элекке хәлен, рәвешен алу, элеккечәгә әйләнү. *Тәне ничек тә үз калыбына кайтыр, җаны да тынычланыр; зиһене генә иләсләнеп китмәсен, ул ялгышса, баш бетте диган сүз...* Г.Гыйльманов. **Үз каны** Үз баласы, туганы. *Көтмәгәндә хатыны үлеп киткәч, Әдиләгә өйләнергә ниятли икән, дигән сүзләр дә йөрде, балалар чит кулга калмасыннар, синең үз каның бит, дип, җизнәсе бик ялына икән, диделәр...* А.Гыйләҗев. *Ничек кермәсен, газиз баласын – үз канын эзләп йөри бит ул...* Г.Гыйльманов. **Үз кесәсен кайгырту** Үз файдасын гына кайгырту, үз ягын гына карау. *Угры түрә, урып җыю эшләреннән бигрәк, үз кесәсен күбрәк кайгырта бит ул.* Н.Вахитов. *Кичә генә партия җитәкчесе булган, илгә тугры хезмәт иткән хуҗа бүген үз кесәсен генә кайгырта башлаган икән, димәк, ул белеп эшли: гайре юлдан дөнья бара алмый!* Ф.Яхин. **Үз кесәсеннән чыгару** Үзең түләү. *Иң киме – ун мең сумнар акча кирәк булыр. Моның яртысын Сарсымбай үз кесәсеннән чыгарса, калганын башкалар күтәрер.* Г.Ибраһимов. **Үз колагы белән ишетү** Кеше аркылы түгел, турыдантуры сөйләгән, әйткән кешедән үзе ишетү һәм шуның дөреслеген раслау. *Ялганлый димәгез, үз колагым белән ишеткәнне сөйлим мин.* Г.Кутуй. *Тик аның шунысы бар: гашыйкларның ничек аңлашканын үз колагы белән ишеткән кеше юк.* М.Маликова. **Үз көенә (көенчә)** 1) *к.* **үз хәлендә**. *Үсмер Тотыш, җегет Тотыш, беркемгә дә баш имичә, койрык тоттырмыйча, үз көенчә яши бирде.* Н.Фәттах; 2) *к.* **үз уңае белән**. *Бу үзгәртеп кору дигәннәре тыныч кына үз көенә яшәп ята торган кырмыска ояларын бутады да атты: ата улны, ана кызны танымаслык хәлгә китерелде мескен халык.* З.Хөснияр. *Вакыт арбасы үз көенә тәгәри бирә.* А.Хәсәнов. **Үз көенә җибәрү** Идарә итмәү, күзәтеп, тикшереп тормау; аерым шартлар куймау; мәҗбүр итмәү. *Тукай премиясе дә ничектер үз көенә җибә-*

*релде.* Казан утлары. **Үз көнен үзе күрү** Берәүнең дә җаваплылыгында, химаясендә булмау; мөстәкыйль яшәү. *Сәке өстендә ыштансыз арт ягың белән шуыша башлаганнан алып, үз көнеңне үзең күрә башлаганчы, тормыш сине кырык сыйрат күпереннән кичерә.* Г.Бәширов. *Синең яшьтән үз көнен үзе күрә башлаган кешеләр бар дөньяда.* В.Нуруллин. **Үз көченә керү** 1) Гамәлгә керү, кулланыла башлау (закон, низам һ.б.ш. тур.). *Әгәр автотуристның җинаять кылуы расланса, монда инде халыкара законнар үз көченә керә.* А.Тимергалин; 2) Чын-чынлап хөкем сөрә башлау, урнашу. *Кыш үз көченә кереп кенә барган бер мәлдә албастылар утарына аю килде.* Г.Гыйльманов. **Үз көчендә калу** Әһәмиятен, дәрәҗәсен югалтмау; гамәлдән чыкмау (закон һ.б.ш.). *Димәк, бер табышмактан бер генә җавап соралу һаман да үз көчендә кала.* Н.Исәнбәт. *Минем тәкъдим үз көчендә кала.* Н.Әхмәдиев. **Үз көчен саклау** Гамәлдә, кулланылышта булу (закон, кагыйдә һ.б.ш. тур.). *Элекке полислар алыштырган вакытка кадәр үз көчен саклыйлар.* Сарман. **Үз кубызына биетү** Үз ихтыярына буйсындыру, үзенчә эшләтү. *Син аны биеттең инде үз кубызыңа!* Н.Кәримова. **Үз кулы белән** Шәхсән үзе. *Ә бәлки, ире соңгы шаһитны үз кулы белән юк иткәндер...* А.Тимергалин. *Үз бәхетен һәркем үз куллары белән төзи, үз куллары белән үк җимерә...* А.Әхмәтгалиева. **Үз кулына алу** 1) Хуҗа булу; 2) Җаваплылыкны, җитәкчелекне һ.б.ш. үз өстенә алу. *Урып җыю эшләрен тулаем үз кулыма алдым.* А.Гыйләҗев. *Инициативаны үз кулыма алырга да ниятем бар.* А.Хәсәнов. **Үз күзе белән күрү** Шәхсән үзе күрү һәм шуның дөреслеген раслап сөйләү. *Безнең ул корзинкада колбаса, алмалар бар, мин үз күзем белән күрдем, әни анда конфетлар да салды.* А.Алиш. --- *малайлар югары оч Әбүзәрнең Әлмәттән әллә нинди кәтүкле кармак алып кайтканын үз күзләре белән күргәннәр.* А.Тимергалин. **Үз күзләренә ышанмау** Гаҗәпләндерә, шатландыра яисә тирән кайгыга сала торган берәр вакыйгага ышанып җитә алмау. *Кечкенә хуҗа, үзе банкротлыкка чыгарган биләмәләрен карап йөргәндә, Васил картның бүлмәсенә дә күз салды, үз күзләренә ышанмыйча, ихахайлап кычкырып җибәрде ---.* Г.Әдһәмова. *Һәм ул бер мизгелдә үз күзләренә үзе ышанмыйча тора, әышангач, моның чынлап та була алуына гаҗәпләнә.* М.Кәбиров. **Үз күзлегеннән карау** 1) Үзенчә бәяләү, үзенең караш, фикер, тәҗрибәсеннән чыгып эш итү. *Өстәвенә һәр кеше дә дөньяга үз күзлегеннән карый.* З.Хөснияр; 2) Кеше фикеренә иярмәү, мөстәкыйль фикерләү. *Кем белә, әнә шул үҗәтлек сукмагы аңа тормышка үз күзлегеннән карарга өйрәткәндер?* Безнең гәҗит. **Үз күрү** *к.* **үз итү**. Үз кырыгы кырык *к.* **үз тугызы тугыз**. *Аларның үз кырыгы кырык, минем хәлемдә эшләре юк.* Н.Әхмәдиев. *Ә Нәсимәнең моңа исе дә китми, аның үз кырыгы кырык.* С.Сабиров. **Үз сиксәне сиксән** *к.* **үз тугызы тугыз**. *Минем сүзгә колак саламыни ул, аның үз сиксәне сиксән.* А.Алиш. *Җәмәгатеңне үзгәртергә тырышма, яшьти, аларның үз сиксәне сиксән!* Г.Гомәр. **Үз сөяге** *к.* **үз каны**. *Җылама, кызым, җылама, син бит безнең кадерле кызыбыз, без сине андый начар кешегә тап булырсың дип үстермәдек, безнең үз сөягебез үзебездән авыр түгел, әлхәмделилла, минем кодрәтем, сине генә тәрбия итәрлек куәтем бар.* Г.Камал. *Карчык, тоныкланып барган күзләрен әлҗе-мөлҗе китереп булса да, ир-атның бертуган апасының улы икәнен (үз сөяге бит!) шәйләп алды.* Ф.Абдуллин. **Үз сүзен әйтү** 1) Мөстәкыйль фикер әйтү; 2) Үзенең барлыгын белдерү, асылын, алдынгылыгын күрсәтү. *Бүгенге драматургия, театр тормышына килсәк, ул үз сүзен әйтте, үзен күрсәтте инде.* Г.Бәйрәмова. *Нәтиҗәдә ул болгарларның бөтенлекле яшәеш панорамасын тудыра һәм аларның икътисад, сәясәт, фән, мәдәният кебек бик күп өлкәләрдә үз сүзен әйткән, мәгълүм уңышларга ирешкән халык булуын раслый.* Китапларда – тарих сурәте. **Үз сүзендә тору** 1) Вәгъдәне үтәү, әйткәнне эшләү. *Күмәк хуҗалык рәисе үз сүзендә торды: Хәлимгә, искерәк кенә булса да, комбайн бирде.* Г.Гыйльманов; 2) Үзсүзле булу. *Юрий кенәз, ыжлап та карамыйча, үз сүзендә торды: «Яртымы, чиреркме – анда бер эшем юк».* В.Имамов. **Үз сүзен итү** Бернигә карамастан үзенчә эшләү, үз фикерен үткәрү. *Ул – үз сүзен итәр өчен бернидән дә курыкмый торган, нинди авырлыкка да риза була торган кыз.* Г.Исхакый. *Күңелендәгечә, үзе дигәнчә эшләүгә каршы төшсәләр, Тимершаның мондый кәмитләр ясый торган гадәте бар, ахыр чиктә барыбер үз сүзен итмичә калмый ул.* М.Хуҗин. **Үз сүзе сүз** Кеше фикеренә колак салмау, үзенчә эшләү турында. *Җиле дә юк, тын җиһан, Табигатьтә Кыш ич хан. Үз сүзе сүз патшаның, Кары калын бакчаның.* Л.Шәех. **Үз тиресенә бикләнү** *к.* **үз кабыгына бикләнү**. **Үз тугызы тугыз** *к.* **үз туксаны туксан**. *Ә исерек Мәүләвинең үз тугызы тугыз, һаман кычкырынуын белә ---.* Г.Кашапов. **Үз туксаны туксан** Кеше фикерен санга сукмыйча, дөрес булу-булмавына карамыйча, үз сүзендә тору. *Гәрчә табиблар килгән саен тынычландырырга тырышсалар да, хатынның үз туксаны туксан иде.* Г.Галиева. *Бер нәрсә башына керсә, чөйләп тә чыгарырмын димә – үз туксаны туксан аның.* В.Гали. **Үз урынына кую** Кемгә яки нәрсәгә дөрес бәя бирү. *Талантны талантсыздан аера белгәннәр, һәркемне үз урынына куя белгәннәр.* С.Хәким. *Аңлар, чыгырдан ычкынган полковникны үз урынына куйса ул гына куяр, дип өметләндек.* Р.Мөхәммәдиев. *Үткән көннәр... Көннәремне гомер иткән әнә кемнәр! Затсызларны үз урынына кую кирәк, – Уйларына хәнҗәр булып уел, йөрәк!* Р.Әхмәтҗанов. **Үз урынына утырту** Азынган кешене тыйнаграк булырга, иерархия, субординация сакларга мәҗбүр итү. *Бүгеннән мин өйдә борылыш башлыйм, һәркемне үз урынына утыртырга бик вакыт.* А.Гыйләҗев. *Бик гарьләнде: тәмам шашты бу мокыт, үз урынына утыртырга вакыт җиткәндер, мөгаен.* М.Әмирханов. **Үз урынын белү** Үз дәрәҗәсен, хәлен, мөмкинлекләрен аңлап эш итү. *Хуҗа булып та йөри шикелле, шул ук вакытта бик үк азынып та китмәгән, үз урынын белә, кечелекле кылана, һәр сүзендә, һәр хәрәкәтендә Люцияне олылау сизелеп тора.* М.Маликова. *Нигъмәтуллин белән җиңешеп, тарткалашып утыруны түбәнлек санаса да, мондый урынсыз дәгъваны, вәсвәсәне шул килеш калдырырга ярамаганны аңлый: һәр инсан үз урынын белеп яшәргә, үзенә анык бәяне белеп үлергә тиеш.* Т.Галиуллин. **Үз урынында** 1) Искечә, элеккечә, үзгәрешсез. *Хәтта почмактагы үрмәкүч оясы да үз урынында.* А.Мансуров; 2) Ничек тиеш, шулай; урынлы булу. *Барысы да үз урынында, төп фикерне ачуга хезмәт итә ---.* А.Әхмәдуллин. *Бар да җитеш, бар да үз урынында.* А.Хәйретдинова.

**Үз хәлендә** Тышкы дөньядагы үзгәрешләргә игътибар итмичә. *Соңгы елларда Гомәр һичбер тәшкиләт берлә бәйләнуын сакламаенча, үз хәлендә Анкарада яши, мөнзәви хәят кичерә иде.* Гасырлар авазы. **Үз хәле хәл** Кеше хәленә керергә мөмкинлеге юк, үзе дә бик авыр хәлдә. *Әмма хәзер Яңгураның үз хәле хәл, башында алар кайгысы түгел иде.* Г.Әпсәләмов. *Милиция ишегалдыннан томырылып чабып чыгып барган атлы кеше бик таныш тоелса да, үз хәле хәл булганлыктан, аны танып өлгермәде Закирҗан.* З.Хөснияр. **Үз эченә бикләнү** Йомылу, аралашмый башлау. *Кайбер түрәләр инде исерешеп йокыга чумды, ә Пётр патша һаман, балтасын суга төшереп югалткан кеше төсле, үз эченә бикләнеп, уйга батып утырды.* В.Имамов. *Болай да үз эченә бикләнеп яшәүче кыз бөтенләй күңеленә йомылды, дәшмәс-сөйләшмәс булды, көннәрен өйдән, авылдан читтә – Җидесу елгасы буенда үткәрә башлады.* Г.Гыйльманов. **Үз юлы белән бару** Үзенчә, үзенә генә хас булганча эшләү, яшәү, фикерләү, мөстәкыйль булу. *[Шагыйрьнең] --- бер бәйләм шигырьләре белән танышып чыккач, бу мәгълүм шагыйрьнең һаман үз юлы белән бара бирүен күрәбез ---.* Казан утлары. **Үз ягына аудару** Үзенә инандыру, фикерен үткәрү. *Хуҗаның кодасы, бер чама белән, сайлауда үз ягына аударып өчен кемгә нәрсә бирергә тиешле булачагын исәпләп карады.* Г.Ибраһимов. *Сөйләүчеләрнең һәркайсының үз сүзе, үз иманы бар, һәрберсе авызын ачып тыңлап торган агайларны үз ягына аударырга чамалый.* Г.Бәширов

**ҮЗ-** Кушма сүзләрдә беренче компонент: 1) Сүзнең икенче өлеше белдерә торган гамәлнең үз-үзенә юнәлгәнлеген белдерә (мәс., *үзконтроль, үзанализ*)

2) Эш-гамәлнең кеше ярдәменнән башка, автомат рәвештә башкарылуын белдерә (мәс., *үзбушаткыч*)

**ҮЗАГАЧ** *и.* Агачларның кайры белән үзәк арасындагы каты тукымасы. *Үзагачта ботаклар никадәр азрак булса, үзагачның кыйммәте шулкадәр югарырак икән.* Г.Әпсәләмов. *Кәүсәнең кисемен гади күз белән яки лупа аша караганда түбәндәге өлкәләрне күрергә була: үзәк, кайры, камбий, үзагач.* Төзү материаллары

**ҮЗАГЫМ** *и.* 1) Сыеклыкларның авыш өслектән үзеннән-үзе агу күренеше. *Малай кушучы белән үзагымда җылына төшкән чишмә суын уртлады.* А.Хәлим

2) *күч.* Үз иркенә куелган эш. *Әмма бездә гасыр буена нәтиҗәле эшләп килгән социаль институтларның аерым структуралары, әйтик, илдәге иҗат берлекләренең үткән юлын өйрәнү, төрле сәбәпләр аркасында үзагымга куелган.* Казан утлары

**ҮЗАГЫМЛЫ** *с.* Үзагымга куелган. *Үзагымлы тормыш*

**ҮЗАГЫШ** *и.* Сыеклыкның табигый авышлык тәэсирендә, насоссыз, компрессорсыз үзе агу күренеше. *Су үзагыш белән килә*

**ҮЗАГЫШЛЫ** *с.* Үзе ага торган, үзе агып китүгә исәпләнгән. *Үзагышлы канализация челтәре*

**ҮЗАЛДЫНА** *рәв.* 1) Үз-үзенә; беркемгә дә мөрәҗәгать итмичә. – *Көтелмәгән яктан бәла килеп, йортны сүтеп кенә ташламасыннар!* – *дип үзалдына укына [ул].* А.Гыйләҗев. *Утардагы атлар картның туктаусыз буылып ютәлләвенә, әледән-әле үзалдына сөйләвенә дә күнеккәннәр инде.* В.Имамов

2) Мөстәкыйль; үз көенә. *Табигать үзалдына яши бирә.* Ш.Галиев. *Елга аръягында үзалдына яши бирде [ул], тирә-якка башкалар да өйләр сала башладылар.* З.Кадыйрова

3) Үзеннән үзе. *Бая, карабодай басуыннан – көртлекләр һәм әкиятләр патшалыгыннан кайтканда уена бәреп кергән сәер фикерләрен хәтерләп, Наилә үзалдына көлемсерәде.* А.Гыйләҗев. *Шулчак, бакча коймасы артында агач мылтыклы малай белән кызчыкны күргәч, үзалдына елмаеп куйды.* А.Фәләх

**ҮЗАЛЛЫ** *с. неол.* **1.** Мөстәкыйль, бәйсез. *Үзаллы тормыш кешесе булгач, үзен Назар абыйсына охшаш кеше итеп күз алдына китерергә тырышты.* А.Хәйретдинова. *Алтын Урда таркалып, Казан ханлыгы үзаллы дәүләт булгач та, казанлылар үз кешеләреннән хан куя алмыйлар – иске традициядән чыгарга базмыйлар – хан итеп Казанга һаман да шул Чыңгыз оныкларын өстерәп китерәләр.* З.Мифтахов

**2.** *рәв. мәгъ.* Мөстәкыйль, бәйсез рәвештә. *Дәүләт белән үзаллы идарә итәргә, производствоны торгызырга, авыл хуҗалыгын саклап калырга, икътисадны аякка бастырырга кирәк.* Р.Миңнуллин. *Район үзәгендә үзаллы тормыш көтә башлагач та, гел кирегә китеп торды барысы.* К.Кара

**ҮЗАЛЛЫЛЫК** *и. неол.* Мөстәкыйльлек. *Башта ике авыл үзаллылык алып, берләшеп карады, шуннан тагын ике бригада оешты, әмма техника, мал-туар, җир бүленгәч, көрчеккә терәлеп, таркалуга дучар булдылар.* Ә.Әминев. *Әмма үсеш һәм стабильлек, бербөтенлек һәм күптөрлелек, үзаллылык һәм интеграция арасындагы капма-каршылыклар кайсыдыр бер якка гына мәңге дә чишелмәячәк, бу хәтта ки философиянең нигез ташларыннан берсе булып тора...* З.Мифтахов

**ҮЗАҢ** *и.* Кешенең шәхес буларак тормышта, җәмгыятьтә үзенең урынын, дәрәҗәсен аңлавы. *Нык, тотрыклы мөнәсәбәтләр булмау нигезе гаиләдә яткан милли үзаң югалуга илтә, чөнки гаиләдә милләт тәрәге булган шәхес тәрбияләү мәсьәләләре арткы планга күчә.* Г.Буби. *Минемчә, моңа фәкать татар халкын бербөтен милләт итеп берләштереп, аның әдәбиятын һәм сәнгатен, мәдәниятен һәм үзаңын үстереп, аны тоташ гыйлемле итеп кенә ирешергә мөмкин.* Р.Кәрами

**ҮЗАҢЛЫЛЫК** *и. ялг. к.* **үзаң**. *Хәзерге заман белем бирү системасында этник үзаңлылык һәм үзтөрлелек исәпкә алынмаса, белем бирүне тулы хокуклы дип атап булмый.* Фәнни Татарстан. *Һәр халыкның дини һәм милли хисләренә ихтирам, бер-берләренең йолатрадицияләренә сак мөнәсәбәт, милләтләрдә үзаңлылыкны үстерү өчен шартлар тудыру, аларның рухи һәм әхлакый кыйммәтләренә таянып эш итү – республикабыздагы тынычлыкның төп нигезен шулар тәшкил итә.* Шәһри Казан

**ҮЗАРА** *рәв.* **1.** Бер-берсе белән; ике яисә берничә зат арасында гына. *Башта тыштагы җил генә шулай үкерәдер дип уйлаган иде, ләкин ике кешенең пыш-пыш үзара сөйләшкәнен ишеткәч, ул уеннан кайтты.* А.Алиш. *Монда җиңел, уйнак юмор, җитди көлү һәм сатирик үткенлек, лиризм һәм драматизм, фаҗига да үзара тыгыз аралашкан хәлдә яшиләр.* А.Әхмәдуллин

**2.** *с. мәгъ.* Бер-берсенә карата булган; берничә зат арасындагы. *Әмма безнең арадагы үзара мөнәсәбәтләребез булачак депутатыбыз белән дөбер-дөбер кайнау ноктасына җитте.* А.Хәсәнов. *Күренер иде, дим, чөнки совет заманында дөнья хәтле нәрсәләр була иде: профсоюз, комсомол, коммунистлар җыелышыннан алып, үзара ярдәмләшү*

*кассасы җыелышларына кадәр йөрисе иде.* Б.Рәхимова

◊ **Үзара гына** Башкаларга белдермичә, ике яисә берничә кеше генә бергәләп. *Инде бүген, шундый чуалчык үйлар ураганда, үзара гына сүз алышырга ярыйдыр бит аларга?!* А.Гыйләҗев

**ҮЗАРАЛАЙ** *рәв. сөйл. к.* **үзара гына**. *Кем ул Лотфулла Нәбиуллин? Үзаралай әйткәндә – талант!..* А.Гыйләҗев. *Анысы, үзаралай әйткәндә, чәпчеми тормыйбыз шул.* Ватаным Татарстан

**ҮЗӘК** *и.* **1.** 1) *мат.* Геометрик фигурада күчәрләр, сызыклар, яссылыклар кисешкән нокта. *Снаряд читкә ерак китмичә («с малым отклонением» урысчасы) барып төшсен өчен, һавада очканда, үзенең үзәк сызыгы тирәсендә әйләнеп очарга тиеш икән.* З.Зәйнуллин

2) Берәр нәрсәнең кырыйларыннан уртасына таба тигез ераклыктагы уйланма төше. *Кояшыбыз суына бара, чөнки аның үзәгендәге ягулык – гидроген кимегәннән-кими.* А.Тимергалин. *Астроном Аристарх Коперникка кадәр үк Галәмнең үзәге Кояш икәнен дәлилли.* М.Әмирханов

3) Нәрсәнеңдер эчке, уртадагы өлеше. *Үзәге суырылган агач син, яфракларың буш, тиздән алар саргаеп коелачак.* М.Әмирханов. *Тиктормас кулларының берсе гөнҗәләнең үзәгеннән үтә күренмәле сүс тарта, ә икенчесе итәк өстендә орчык биетә.* М.Садыйков

4) Кайбер җиһаз, җайланмаларның төп функцияне башкара торган яисә аларны тотып тору өчен махсус ясалган өлеше, күчәре. *Карандаш үзәге. Урама үзәге*

5) Торак пунктларның административ, сәүдә биналары һ.б.ш. урнашкан өлеше. *Шәһәр үзәге, андагы данлыклы сарайлар, храмнарны Ренессанс чорында Италиядән килгән данлыклы архитекторлар төзегәннәр.* М.Юныс. *Кышкы кичләрнең берсендә студент иптәшем фатирда торган Кәҗә бистәсеннән, троллейбуска утырып, соң гына үзәккә кайтып килешем.* А.Тимергалин

6) Берәр илнең, өлкәнең җитештерү, мәдәният, ял итү һ.б.ш. ягыннан әһәмиятле эре торак пункты. *Җәнлек тиреләре төяп, ханлыкның бөек үзәге шәһре Казанга барып, олау тутырып, тимер әйберләр алып кайтты.* З.Мурсиев

7) Көнкүрештә кулланыла торган, гадәттә җырлар, көйләр тыңлау өчен акустик системасы, кассеталы яки дисклы магнитофоны, грампластинкалар тыңлау, Интернетка тоташу җайланмалары һ.б.ш. булган аппаратура комплексы. *Ярый әле Канәфи каушау дигән нәрсәне белми: шундук стереомузыка үзәген тоташтырды, һәм иркен кабинетны «Әллүки»нең савыктыргыч аһәңнәре күмеп китте, аннары ачык тәрәзәдән, ишелеп-ишелеп, язгы салкынча сирень исләре килеп керде...* А.Тимергалин

8) Биналарга җылы су, җылылык бирү чылбырындагы чыганак. *«Бишбармак принцибы»на нигезләнгән биш бүлмәле эсселе-суыклы мунчалар төзү, үзәктән ягып җылыту, шул мунчада хушланып чыккач, шахмат уйнап утырулар, сабын кайнату, акча сугу һ.б. – болар бит мәдәни халыкларга гына хас!* А.Тимергалин

9) *физиол.* Организмның берәр функция эшчәнлеген җайлап торган нерв күзәнәкләре төркеме. *Кайбер нерв үзәкләренең чамадан тыш активлашуы күзәтелә.* М.Маликова. *Күрү үзәге*

10) *тех.* Станокта эшкәртү өчен деталь урнаштырылган күчәр. *Динамо белән двигательнең үзәкләре төптөгәл туры килергә тиеш икән, моны центровка диләр, югыйсә зур тизлектә әйләнгән механизмнар калтырый башлый һәм ватылып чыга.* З.Мурсиев

11) Берәр эшчәнлек, җитәкчелек эшләре тупланган урын. *Штаб – төзелешне координацияләү үзәге.* Ф.Абдуллин

12) Берәр төр эшчәнлек белән җитәкчелек итүнең югары органы. *Икенче көнне, үзәктән махсус комиссия килеп, тикшерү эшләре башлап җибәрде.* Ф.Хуҗин. *Урман торгызу эшенә акчаны үзәктән бирәләр ---.* З.Мурсиев

13) *күч.* Нинди дә булса әһәмиятле эшчәнлек башкара торган учреждение яки бүлек. *Гыйльми үзәкнең конференцзалында, мәрмәр коридорларында: «Борынгы Кытай иероглифларына күз салсаң...», «Санскрит язмаларына караганда...», «Борынгы Мисыр папирусларында...» дигән сүзләр яңгырап торды.* Г.Афзал. *Хәрби хезмәткә алынгач, Хәбирне сержантлар әзерли торган укыту үзәгенә билгеләделәр.* Ф.Хуҗин

14) *күч.* Төп, асыл юнәлеш. *Барлык һәм юклыкның, үзәк һәм периферияне, зарурлык һәм очраклылыкның төп үлчәме булып кеше исәпләнә.* С.Поварисов. *Алар, үзләре дә сизмичә, бер теориядән икенчесенә, бер фараздан икенче фаразга күчәләр, ләкин әңгәмәнең үзәге һаман бер: эвристика, иҗади фикер эшчәнлеге...* А.Тимергалин

15) *күч.* Төп вакыйгалар булган урын. *Арыслан шул көннәрдә генә сөргеннән кайтты, карт исә Сары Арканың аяклы хәбәрчесе, партия, кабилә талашларының барлык интригаларының үзәгендә кайнаучы иде.* Г.Ибраһимов. *Булып кына калмаганнар, андагы мәхшәрнең үзәгендә булганнар, үлемнең бугазына кереп йөргәннәр...* Г.Гыйльманов. *Соңгы хәбәрләрнең үзәге безнең өй иде бүген.* Н.Кәримова

16) *күч.* Төп башкаручы, оештыручы. *Чыннан да, җәмәгать, эшне башкарып чыгу өчен җаваплы кешене – төп үзәкне билгеләү дөрес булыр.* Ф.Яхин

17) *күч.* Җан, йөрәк, күңел. *Сезнең җырларыгыз үзәккә үтеп керә, тетрәндерә.* Р.Сәгъди

18) *күч.* Сурәтләү объекты, сурәтләнгән төп вакыйга. *Әсәрнең үзәгендә авыл тормышы, төгәлрәк әйткәндә, сугыш еллары һәм сугыштан соңгы чор татар авылы тора.* Р.Батулла. *– Менә, балалар, иншаның үзәгендә зур вакыйга да юк сыман, әмма Мөдәррис гади генә хәлне дә мавыктыргыч итеп яза белгән, – дип нәтиҗә ясады әдәбият укытучысы.* Х.Гайнетдинов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Нәкъ уртадагы; нәрсәнең дә булса уртасына урнашкан. *Сәхнәдә бик күп әйберләр эленгән, үзәк урында шәҗәрә урын алган.* Н.Кәримова. *Үзәк ял паркына кадәр автобуска утырып килделәр.* Г.Гыйльманов

2) Беренчел, төп. *Бу чишмәләр үзләренең көчен әлеге үзәк, тамыр чишмәгә биреп тора кебек...* Г.Гыйльманов

3) *күч.* Төп, иң әһәмиятле, үз тирәсендә башкаларны берләштергән. *Күпме генә вакыт үткәндер, Мансур, бакчаны үзенең көмеш тамчылары белән сафландырган фонтан кебек, коллективта үзәк бер урынны биләп алды.* Ф.Садриев. *Таң нурыдай алсу мәк чәчәген без Күчереп чиктек бары кул яулыгына. Шушы гүзәл бизәк үзәк дәлилдер Безнең заманаңның уяулыгына.* Ф.Гыйззәтуллина

4) *күч.* Җитәкчелек итә торган; баш, югары. *Шейнкман председательлегендә үткән бу киңәшмәдә --- мөселман полкы оештыру, Петроградтагы Үзәк Комитет тибындагы губерна үзәк власте органы төзү турындагы мәсьәләләр каралды.* М.Хәсәнов. *Сез, иптәш сержант, үзәк аэродромга барып карагыз.* Ф.Хуҗин

5) *күч.* Югары, җитәкче оешмалар башкара торган, шулардан чыккан, шулар оештырган. *1945 елгы җиңүгә 30 ел*

*тулганда, 1975 елның май аенда, Гаврилов белән үзәк телевидениедә очрашу тапшыралар.* З.Зәйнуллин

◊ **Үзәккә тию** *к.* **үзәккә үтү**. *Җан ияләренең теңкәсен корытырлык зәмһәрир суыклар тора. Үзәкләргә тия.* М.Хәсәнов. **Үзәккә төшү** *к.* **үзәккә үтү**. *Газизнең эндәшүен ул инде хәзер ишетми, ишетсә дә, мыскыллануы аның үзәгенә төшкән.* Ф.Яхин. **Үзәккә үтү** 1) Бик каты интектерү, җанга тию (авыр хәл, хис, һ.б. тур.). *Әле кай төшендәдер чәнчеп-чәнчеп алды, әле, үзәкләргә үтеп, күңел күген ачы сагыш басты; ул сагыш, беленер-беленмәс кенә әрнү булып, җанын бертуктаусыз борчыпбимазалап интектерде...* Г.Гыйльманов; 2) Бик өшетеп, юешләтеп азаплау (җил һ.б.ш. тур.). *Ичмасам, җилләнгыры үзәккә үтмәс иде ---.* З.Мурсиев. *Туңды, үзәгенә үтәрдәй булып эченә суык төште.* М.Хәсәнов. **Үзәк көю** *к.* **үзәк өзелү.** *Дәресләрдән соң бала җанлы педагог, малай өчен үзәге көеп, колония баракларына карап юнәлде.* З.Мурсиев. **Үзәкне өзү** Күңелгә авыр тәэсир итү, сагышка, борчуга, кайгыга салу. *Кичләрен ятакханәдә концертлар оештырыр, үзәкләрне өзә торган моңлы тавышы белән бетмәс-төкәнмәс халык җырларын башкарыр.* Р.Батулла. **Үзәк өзгеч** 1) Тетрәндергеч; кызгандыра торган; тәэсирле. *Тавышы шагыйранә моңлы иде, лирик җырларны үзәк өзгеч аһәң белән башкара.* М.Әмирханов. *Әнием: – Исә-ә-ән!.. – дигән үзәк өзгеч сүз белән өстемә каплана.* Р.Рахман; 2) Бик каты, көчле (суык, җил һ.б.ш. тур.). *Шуңа күрә ачыклыкта калган берничә йорт көзге ачы җилләр, кышкы үзәк өзгеч бураннар хакимлегенә калган.* Ф.Хуҗин. **Үзәк өзелү** Нинди дә булса авыр хис-кичерешләрдән бик борчылу, өзгәләнү. *Өмете өзелми аның, бәхетсезлектән үзәге өзелә.* Н.Кәримова

**ҮЗӘККӘ́ ОМТЫЛУ** *и. физ.* Әйләнмәле хәрәкәттә барлыкка килгән көчәр үзәгенә периферияддән омтылу көче. *Үзәккә омтылу көченең гаять зур булуы нәтиҗәсендә алар керне бик нык «бомбага» тота башлый.* Ватаным Татарстан

**ҮЗӘКЛӘНҮ** *ф.* 1) Ашлык сабакка утыру

2) Шешнең уртасында каты өлеше барлыкка килү

**Үзәкләнә башлау** Үзәкләнү билгеләре күренү

**Үзәкләнеп алу** Кинәт үзәкләнү. *Канат җәйде каен җилләге. Үзәкләнеп алды балтырган. Табигать киң: сез бит тар, димәде, Җәй иярде кояш артыннан.* *М.Әгъләмов*

**Үзәкләнеп җитү** Тиешле дәрәҗәдә үзәкләнү

**Үзәкләнеп килү** *к.* **үзәкләнә башлау**

**ҮЗӘКЛӘШТЕРЕЛҮ** *ф. төш. юн. к.* **үзәкләштерү**. *Оста сәясәтче һәм талантлы гаскәр башлыгы булган Кубрат үзәкләштерелгән дәүләт төзи алган, һәм шул чор чыганакларында бу дәүләт хаклы рәвештә «бөек» дип зурлап йөртелгән.* Р.Фәхретдинов. *Колхоз һәм совхозлардагы посёлокларны тулысынча үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү, барлык йорт һәм квартираларга газ кертү эшләре төгәлләнәчәк.* Г.Усманов

**Үзәкләштерелә бару** Торган саен ныграк үзәкләштерелү. *Көннән-көн мәгариф системасы, университетлар белән идарә итү эше ----үзәкләштерелә бара...* Ватаным Татарстан

**Үзәкләштерелә башлау** Үзәкләштерелергә тотыну

**Үзәкләштерелеп бетү** Тулысынча үзәкләштерелү. *Кызганычка каршы, бик тә төрки мәдәниятле булган, ләкин үзәкләштерелеп бетмәгән караханилар дәүләтен XI гасыр азагында (бәлки, Баласагуни үлеп тә өлгермәгәндер) монгол телле мәҗүси каракытайлар тармар итә ---.* Р.Әхмәтьянов

**Үзәкләштерелеп килү** Күптәннән эзлекле рәвештә үзәкләштерелү

**Үзәкләштерелеп тору** Даими, әледән-әле үзәкләштерелү; хәзер үзәкләштерелү

**ҮЗӘКЛӘШТЕРҮ** *ф.* 1) *тех.* Үзәккә карата дөрес урнаштыру

2) Бер үзәктән, бер чыганактан күпләгән урыннарга, гадәттә, йортларга җибәрү (су, җылылык һ.б.ш тур.). *Быел да торакларны үзәкләштереп җылытудан шәхси җылыту системасына күчерү эшләре башкарылган.* Ватаным Татарстан. *--- эчәр су пластик шешәләрдә китерелә, көнкүрешкә дигән техник су да эчәргә яраклы, һәм ул юыну урыннарына үзәкләштереп җибәрелә ---.* Татар заманы

3) Бер үзәккә буйсындыру. *Иң ышанычлысы – ведомстводан тыш сак хезмәтенең үзәкләштереп саклау пультына тоташтырылган сигнализация җиһазлау.* Идел. *Мондый ысулга резерв федераль банклар ставкаларын билгеләү, дәүләт бюджеты дефицитын киметү, товар һәм хезмәт күрсәтүне үзәкләштереп башкару, салым сәясәте кирә.* Туган як

**Үзәкләштерә төшү** Бераз үзәкләштерү; тагы да үзәкләштерү

**Үзәкләштереп бетерү** Тулысынча үзәкләштерү. *Беренче елларда әле большевиклар партиясенең тормышының һәр өлкәсен үзәкләштереп бетерергә көче житми.* Казан утлары

**Үзәкләштереп килү** Күптәннән бирле эзлекле рәвештә үзәкләштерү

**Үзәкләштереп тору** Булган берсен үзәкләштерү; әле, хәзер үзәкләштерү. *[Ул]: «Теләсә нинди илдә, хәтта Россия кебек катлаулы федератив дәүләттә дә, вәкаләтләрне һаман саен үзәкләштереп тору мөмкин түгеллеге бәхәссез», – диде.* Ватаным Татарстан

**ҮЗӘКЛӘШҮ** *ф.* Бер үзәккә карый башлау, бер үзәккә буйсыну; бер үзәккә туплану. *910–1392 С температура аралыгында тимернең кристаллик рәшәткәсе яңадан үзгәрә, һәм аның атомнары периоды 0,364 нм булган куб кырларына үзәкләшәләр ---.* Төзү материаллары

**Үзәкләшә башлау** Үзәкләшергә тотыну

**Үзәкләшеп бетү** Тулысынча үзәкләшү

**Үзәкләшеп килү** Әкренләп үзәкләшү

**Үзәкләшеп китү** Тиз арада үзәкләшү. *Аларны эреләндерергә тырышучылар, чыгымнарны киметәчәк, дисә, моңа каршы килүчеләр артык үзәкләшеп китүдән һәм мәдәни йөзне югалтудан курка.* Казан утлары

**Үзәкләшеп кую** *к.* **үзәкләшеп китү**

**ҮЗӘКЛЕ** *с.* 1) Үзәге булган. *Виноград, виноград, виноград үзәкле, Бер танышып аерылгач, өзә икән үзәкне.* Җыр

2) Үзәге билгеле сыйфатларга ия булган. *Казан ишекләре бизәкле, күгәннәре бакыр үзәкле.* Р.Харис. *Нарат – сумала юллары булган үзәкле токым.* Төзү материаллары

3) *күч.* Нык характерлы, чыдам, максатчан. *Әдәбият үзәгендә һәрчак иҗтимагый яктан нык үзәкле шәхесләр торган.* Р.Фәйзуллин. *Ул исемнәр үзләре үк гади, әмма нык үзәкле һәм ышанычлы кешеләр турында сөйли.* М.Вәли-Барҗылы

**ҮЗӘКТӘ́Н КУУ** *и. физ.* Әйләнмәле хәрәкәттә барлыкка килгән көчәр үзәгеннән периферияга омтылу көче. *Ай кебек зур кисәк аерылу өчен, Җирнең әйләнү тизлеге һәм үзәктән куу көче бик зур булырга тиеш, ә андый мөмкин-*

*лек юк диярга була*. Фән һәм тел. *Үзәктән куу ысулы белән әзерләнгән бетон катнашмасын тыгызлау өчен, бу катнашма салынган форма әйләнгән вакытта туган үзәктән куу көче файдаланыла.* Төзү материаллары

**ҮЗӘКТӘШ** *с. мат.* Бер үзәк нокта тирәсенә урнашкан, концентрик. *А.Гыйләҗев һәрвакыт татар дөньясы элементларын системалаштырырга тырыша, моның өчен үзәк һәм аннан ерагайганда барлыкка килгән үзәктәш әйләнәләрне аерып чыгара.* Казан утлары

**ҮЗӘКТӘШЛЕК** *и.* Үзәктәш булу. *Әйләнмәләрнең үзәктәшлеге*

**ҮЗӘКЧЕЛЕК** *и. сәяси к.* **централизм**

**ҮЗӘН** *и.* **1.** 1) Таулы урында буйга сузылган уйсу тигез җир, уйсулык. *Такырны артта калдырып, үзәннән бара башлагач, машина тагын шып туктады.* А.Гыйләҗев. *Менә, шулай итеп, елга буйларын ташлап күченергә мәҗбүр булган тал балалары, ачык ялан-далалардан тыш, биек тауларда, кыялы үзәннәрдә дә яшәргә өйрәнгәннәр.* А.Хәлим

2) Елга юлы буендагы тигезлек; коры елга буе. *Елга үзәне буйлап бераз өстәрәк каяндыр югарыдан гөбердәп ишелеп төшкән су тавышы билән алды аны.* А.Хәлим. *Марстагы борынгы елга үзәннәре, --- Уран белән Нептунның боҗралары, дистәләрчә яңа иярченнәр һ.б.ш. кебек ачышларны ябып куярга, мәктәп дәреслекләреннән алып ташларга кирәк була!* А.Тимергалин

**2.** *с. мәгъ.* Уйсу җирдә урнашкан. *Дөрес, шәһәрнең төп өлеше хәзер үзән җирдә түгел, тау башында.* А.Тимергалин

**ҮЗӘНЛӘНҮ** *ф. махс.* Түбәнлеккә, иңкүлеккә, болынга әйләнү

**ҮЗӘНЛЕ** *с.* Үзәне булган; үзәнләнеп торган. --- *Шумердан көнчыгыш якта, таулы һәм үзәнле җирләрдә, бик борынгы заманнарда ук Элам дигән дәүләт булган.* Н.Фәттах. *Идел үзәнлегендә һәм көнбатышта Сура үзәнлегендә түбән эрозия базисы булуы, шулай ук җирнең көпшәк һәм тиз уалучан токымнардан торуы бу тирәләрдә тирән үзәнле вак елгалар һәм ерым-сызалар челтәрен барлыкка китерә.* Б.Хәмидуллин

**ҮЗӘНЛЕК** *и.* Үзәнле, үзәннәре булган урын; уйсулык, иңкүлек. *Мин белгән бүтән авыллар барысы да үзәнлектә, су буенда урнашкан.* В.Нуруллин. *Үзәнлекләр эченнән сузылып барабара, көзге сыман ялтырап яткан күл буена җиттеләр.* В.Имамов

**ҮЗӘНСУ** *с.* Үзәнгә тартым, үзәнгә охшаш; уйсу. *Үзәнсу җирне ак томан каплап алган.* Т.Нурмөхәммәтов. *Бүген минем биләмәләремдә төрле кишәрлекләр бар – үзәнсу урыннарда бөртекләләр уңышы начар түгел.* Ютазы таңы

**ҮЗБАШ** *рәв.* **1.** Мөстәкыйль рәвештә; үзе генә. --- *сиңа киңәшем шул булыр, килен: үзбаш хәл итмә, барысын да Бәһрам бәк кайткач хәл итәрсез.* М.Хәбибуллин. *Ул телдә, фикердә, гамәлдә бүтәннәргә тагылмый, ятлар җырын җырламый, үзбаш юл ярып бара.* Т.Әйди

**2.** *с. мәгъ.* Мөстәкыйль, ирекле, буйсынмаган. *Анда да син түзден, рәнҗү сакламадың; ниһаять, син яңа, үзбаш мәмләкәткә нигез салдың, күп җиңүләргә ирештең.* Р.Батулла. *Төймә саен – үзбаш дәүләт, ил...* И.Диндаров

**ҮЗБӘК** *и.* Башлыча Үзбәкстанда һәм аңа күрше өлкәләрдә яши торган төрки телле халык һәм шул халыкның бер вәкиле. *Ул Ташкент базарын күрсәгез икән, ул сатучы үзбәкләр: «Әкә, нугай әкә!» – дип өзелеп торалар, татарларны яраталар.* А.Гыйләҗев. *Үзбәк кешесенә кияүгә чыгып, аның белән Ташкент якларына китәргә ниятләгәнен язган иде үги ана.* А.Әхмәтгалиева

**ҮЗБӘ́КЧӘ** *рәв.* **1.** 1) Үзбәк телендә. *Аларның кайберләре берничә телдә, мәсәлән, негрлар тормышын яктырткан «Алар хакында кыйсса» татарча, урысча, үзбәкчә языла.* Т.Әйди. *– Ойвай, мән сезне аңламасман... – дип, үзбәкчә берничә сүз әйтә дә китеп бара Әхмәт.* С.Поварисов

2) Үзбәк халкындагыча. *Биюче хатынның үзбәкчә биегәнен күзәткәндә, халык берничә тапкыр аһ итте.* Р.Гаязетдин. *Безгә дә хат язган ---, минем туачак нәниемә күп бүләкләр, үземә, авырлы вакытымда кияр өчен, үзбәкчә бөреп тегелгән киң күлмәк җибәргән.* Г.Галиева

**2.** *с. мәгъ.* 1) Үзбәк телендәге. *Симиниев --- үзбәкчә җыр сузып җибәрде.* Т.Әйди. *Үзбәкстанда яши һәм үзбәкчә китап укый-укый, үзбәк белән бик нык якынайган икән.* Н.Фәттах

2) Үзбәк халкына хас. --- *чапан яки үзбәкчә түбәтәйләр киеп кенә үзбәк булмый, аның эчендә татар моңы саклана, шуңа ул татар булып кала.* Р.Вәлиев. *Күпме генә тырышып карасам да, әнинеке кебек үзбәкчә пылауны, телеңне йотарлык бәлешләрне пешерә алганым юк әле.* Шәһри Казан

**3.** *и. мәгъ.* Үзбәк теле. *Хисами үзбәкчә өйрәнә башлаган иде инде.* Ф.Абдуллин. *Каян, ничек өйрәнеп өлгергәндер, бу үзбәкчәне дә борчак сыман сибә генә иде ---.* В.Имамов

**ҮЗБӘ́КЧӘЛӘП** *рәв.* 1) Үзбәкләрдәгечә; үзбәкләрнең матди, рухи мәдәниятенә хас булганча. *Үзбәкстанга барасың: шул ук татар, әмма инде ул үзбәкчәләп пылау ашый башлаган, киеме дә бераз үзгәргән.* Р.Вәлиев

2) Үзбәк телендә. *Габдулла үзбәкчә киенеп, чапаны астына браунингын яшереп, базарларга чыга да шиклерәк ир-атка үзбәкчәләп, таҗикчалап: – Әкә, сездә сатлык корал булмасмы икән? – дип мөрәҗәгать итә иде.* Т.Әйди. *Үзбәкчәләп җавап бирү*

**ҮЗБӘ́КЧӘЛӘТЕП** *рәв. к.* **үзбәкчәләп.** *Кичләрен Рушан белән үги әтисе уллары үзбәкчәләтеп ясап куйган айванда, урысча әйтсәк – беседкада утыргалыйлар ---. Р.Мирхәйдәров*

**ҮЗБӘ́КЧӘЛӘШТЕРҮ** *ф.* 1) Үзбәк халкына хас сыйфатларны ачыграк, калкурак итеп күрсәтү, күбрәк чагылдыру

2) Үзбәкчәгә, үзбәк теленә тәрҗемә итү. *Шуңа күрә Нурания «Кызыл сучы» газетасы редакциясендә тәрҗемәче вазифасын башкарырга, Җамалия исә, сынауны узгач, нәшрият өчен дәреслекләрне үзбәкчәләштерергә керешә.* Т.Әйди

**Ү́ЗБЕЛДЕКЛЕ** *с.* **1.** Үзенә артык ышанган; артык мөстәкыйль эш итә торган. *Я, алай бик үзбелдекле булгач, кунак каршында дөресен әйтеп бир...* К.Кәримов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Рөхсәтсез, үз теләкихтыяҗларыннан гына чыгып. *Моннан тыш, лесничий, урман хуҗалыгы хезмәтчәннәрен урап узып, чыршыны үзбелдекле кисеп алып кайткан кеше өчен бәйрәм чыгымы бермә-бер артачагын, моның өстенә шактый нерв тузачагын да искәртергә онытмады.* Ютазы таңы

2) *сөйл.* Үзалдына, үзе белгәнчә, үзлегеннән өйрәнгәнчә. *Ә авылларда мәет җирләү, Коръән ашларын уздыру – үзбелдекле укыган, азрак белемлерәк әби-бабайлар кулында.* Безнең гәҗит

**Ү́ЗБЕЛДЕКЛЕЛӘНҮ** *ф.* Үзбелдеклелек күрсәтү; башкаларны тыңламыйча, үзенчә генә эшләү. *Ул, үзбелдекләнеп, ферма төзетәсе кирпечтән Мәркәгә йорт салып бирде.* Ә.Гаффар. *Кешенең, үзбелдекләнәнеп, чиргә каршы көрәшергә тырышуы еш кына файда урынына зыян китерә.* Туган як

**Ү́ЗБЕЛДЕКЛЕЛЕК** *и.* Үзбелдекле булу сыйфаты. *Адәмдә үзбелдеклелек көчле.* Г.Хөсәенов. *Анда: «Музей эшен-*

*дә күрсәткән башбаштаклыклары һәм үзбелдеклелеге өчен, мөдир Кәбиров Солтан Җәләевичкә шелтә белдерергә!» – дип язылган иде.* Ф.Яхин

**ҮЗБИЛГЕЛӘНЕШ** *и.* 1) Шәхеснең социаль мөнәсәбәтләр системасында үз урынын аңлы рәвештә билгеләве; *русчасы:* **самоопределение**. *Очрашуларның максаты – аларның һөнәри үзбилгеләнеше.* Биектау хәбәрләре

2) Милләтнең үз милли дәүләтчелеген төзү хокукы. *Сүз милләтләрнең үзбилгеләнеше турында бара.* З.Мурсиев. *Аның әйтүенчә, безнең заманның төп идеяләренең берсе – халыкның үзбилгеләнеш принцибы.* Өмет

**ҮЗБИЛГЕЛӘНҮ** *и. к.* **үзбилгеләнеш**. *Комитет ел саен ике конференция үткәрә, брошюралар чыгара һәм җәмәгать фикерен халыкларның үзбилгеләнү хокукын яклауга җәлеп итә.* Т.Әйди. *Европалылар белән бер дәрәҗәдә үк Азия һәм Африка халыкларының да милли үзбилгеләнүгә хокуклы икәнлекләрен танырга вә шул юлда аларга хәл кадәре ярдәм кылырга кирәк.* Р.Мөхәммәдиев

**ҮЗБУШАТКЫЧ** *и. мех.* **1.** Кузовтагы йөген механик рәвештә күтәртеп яки аударып бушата торган йөк машинасы. *Бүлектә буш машина калмаганлыктан, алар юл уңаенда бер үзбушаткычны туктаттылар һәм, шуңа утырып, Казансу буендагы яңа кварталларның берсенә килеп җиттеләр.* Т.Әйди. *Безнең яннан, дөбердәп, иләмсез дәү үзбушаткыч узып китте.* А.Гыйләҗев

**2.** *с. мәгъ.* Махсус җайланмасы ярдәмендә үз йөген үзе бушата торган. *Ул арада машинаның үзбушаткыч әрҗәсе, күктәге кояшны да каплап дигәндәй, өскә күтәрелә башлады.* Ф.Баттал. *Тыкрык башындагы үзбушаткыч машинага болар, мөгаен, терлекләр төямәкче иде.* Н.Гыйматдинова

**ҮЗГӘ** *с.* Башкалардан аерылып торган, аларга охшамаган, башка, бөтән; үзенчәлеге булган. *Кешеләрнең язмышы бер-берсенекенә охшамаган кебек, буыннарны да үзләренә генә хас, үзгә язмыш көтә.* А.Гыйләҗев. *Ләкин үзгә стиль агымы да юк түгел.* А.Әхмәдуллин

**ҮЗГӘЛӘНҮ** *ф.* Үзгә булып китү; башкача төс алу; үзгәрү. *Профсоюзның карашы, тавышы үзгәләнде ---.* А.Гыйләҗев. *Әллә заман үзгәргәнгә, Әллә язмыш көлгәнгә, Бөтен нәрсә үзгәләнә Яңа елга кергәндә.* К.Булатова

**Үзгәләнә бару** Акрынлап үзгәләнү; торган саен күбрәк үзгәләнү

**Үзгәләнеп китү** Көтмәгәндә үзгәләнү

**ҮЗГӘЛӘҮ** *ф.* 1) Чит күрү, үз санамау. *Урын үзгәләпме, нindидер йокысыз төн кичерделәр.* М.Мәһдиев

2) Теләсә нәрсә ашамау, аш талымлау. *Аш үзгәләү*

**Үзгәләп алу** Беркадәр вакытка, бераз үзгәләү

**Үзгәли башлау** Үзгәләргә тотыну

**ҮЗГӘЛЕК** *и.* Үзгә булу, аерылып тору күренеше; аерма, башкалык. *Кеше дигәнең инкубатор чебеше түгел, башка күп җәһәттән алар бер-берсенә охшасалар да, күңел ягына килгәндә, адәм уллары үзгәлеккә омтылырга тиешләр!..* А.Гыйләҗев. *Пар үгез җигелгән арба артыннан тузанлы юл буйлап атлаучы чуар төркем генә даланың бертөрле күренешенә үзгәлек кертә.* Т.Әйди

**ҮЗГӘЛЕКЛЕ** *с.* Үзгәлеге булган, аерылып торган. *Трагедияләргә гади драма әсәреннән үзгәлекле стиль хас.* Әдәбият

**ҮЗГӘРЕШ** *и.* 1) Үзгәрү, икенче төрлегә әверелү күренеше һәм шуның нәтиҗәсе. *Йөрәк – гади насос лабаса, йөрәкнең үзгәреш, тайпылыш законнарын да белә алмагач инде!* А.Гыйләҗев. *Юк, син көлмә, чыннан да, бүлмәдә нindидер бер үзгәреш, алмашыну сиздем.* А.Тимергалин

2) Үсеш, алга китеш. *Маймылда аң һәм сөйләм теле барлыкка килү дә сикерешле, ягъни кисәк үзгәрешләр аркасында булган.* А.Тимергалин

**ҮЗГӘРЕШЛЕ** *с.* **1.** 1) Үзгәреше булган, аерма күренеп торган. *Мәсәлән: «Ант», «Кыр казы», «Әткәем» һәм башка шигырьләрнең бераз гына үзгәрешле ике варианты булуы шул турыда ачык сөйли.* Фән һәм тел

2) Кинәт яки көтмәгәндә үзгәреп тора торган; үзгәрүчән. *Андый идем, мондый булдым, димим, Гөнаһлардан тәүбә кылдым, димим, Холкым үзгәрешле, диюем.* И.Сабиров. --- *Салават абыйда, әле йөрәге жу итеп, әле яңадан кояшы чыгып, ае калкып, яңгыры да явып үткәндәй, бер-бер артлы үзгәрешле күңел халәтләре булып алды.* Ф.Яхин

**2.** *и. мәгъ.* 1) *мат.* Алгебраик аңлатмада нindидер санны белдергән символ. *Әгәр үзгәрешле кергән аңлатмада һәр үзгәрешле урынына аның нинди дә булса кыйммәтен куйсак, санлы аңлатма барлыкка килә.* Алгебра. *Үзгәрешлеләрне ике якка аерып, ике ягыннан да интегралга алыйк.* Фән һәм тел

2) *информ.* Адресы мәгълүматларга керү һәм программаны үтәгәндә бирәмлеген үзгәртү өчен кулланыла алган исемле яки башкача адресланган хәтер өлкәсе

**ҮЗГӘРЕШСЕЗ** *с.* **1.** Үзгәрми торган, үзгәрешләр күзәтелмәгән. *Бу үзгәрешсез ак төс, бу хәрәкәтсезлек Мөниранә тәмам туйдырды.* Г.Әпсәләмов. *Үзалдына йомылып, сүзсез йөрсә дә, кагу-сугуны белмәгән бу хуҗасы белән айлар буе дәвам иткән үзгәрешсез, төссез тормышта алар үзара килешкән, иләшкән иде инде.* В.Имамов

**2.** *рәв. мәгъ.* Үзгәреш кертмичә, үзгәрмичә; искечә; гадәттәгечә. *Аларның өйдә уздырган кичләре дә басу буразналары шикелле гел бертөрле, һаман үзгәрешсез кабатлана.* В.Имамов. *Ул кабиләләрнең рухи дөньясына караган иң әһәмиятле күренешләр меңәр еллар аша бүгенге көннәргә кадәр үзгәрешсез диярлек килеп җиткән.* Г.Дәүләтшин

**ҮЗГӘРЕШСЕЗЛЕК** *и.* Үзгәрешсез булу күренеше; даимилек, тотрыклылык. *Бу – этнологлар һәм тарихчылар арасында этносларның барлыкка килүе турында автохтон һәм эволюцион, аларның «милли» сыйфатларының үзгәрешсезлеге һәм җитди эчке үзгәрешләрсез гадидән (кабилә) катлаулыга (милләт) күтәрелеше буларак этник үсеш турындагы карашлар өстенлек итүе белән аңлатыла.* Кызыл таң

**ҮЗГӘРМӘ** *с. махс.* Үзгәрә торган. *Үзгәрмә зурлык. Үзгәрмә йолдыз*

**ҮЗГӘРМӘС** *с.* Үзгәрми торган; даими; тотрыклы. *Туган илеңә, халкыңа бирелгәнлек, туган телеңә сүнмәс мәхәббәт – менә ул язучының үзгәрмәс кыйблалары!* А.Гыйләҗев. *Шуның аркасында китапның асылында халыкара үзгәрмәс, универсаль элементлар күп, һәм китапның исеме башка милләт яки башка дин кешеләрен артык сагайтмаска тиеш.* А.Тимергалин

**ҮЗГӘРТЕ́П КОРУ** *и.* СССРда 1985–1991 елларда икътисадта базар мөнәсәбәтләрен урнаштыруны, гомумән, халыкның дөньяга карашын, иҗтимагый тормышны демократик принципларга таянып үзгәртүне максат иткән дәүләт сәясәте. *Бу хәл күптән булды, әле ул вакытта үзгәртеп кору да, коммунизм-социализм төзү дә юк, бары тик череп баеган капитализм гына иде.* А.Гадел. *Үзгәртеп кору чоры*

*әдәбият белеменә дә зур үзгәрешләр китерде.* А.Әхмәдуллин

**ҮЗГӘРТКЕЧ** *и. махс.* Бер төр зурлыкларны (энергия, ток, сигнал) кулланырга җайлы булган икенче төрлесенә үзгәртә торган җайланма; *русчасы:* **преобразователь**. *1975 елда Рәшит Шакир улы, академик А.Н. Фрумкин һәм СССР ФАнең вице-президенты В.А. Котельников булышлыгы белән, КАИда электрохимик информация үзгәрткечләре лабораториясен оештыра һәм аны җитәкли.* Фән һәм тел. *Өч торак пункттагы сусуырткыч җайланмаларына челтәрдә даими басым торарга мөмкинлек бирә торган ешлык үзгәрткечләре урнаштырылган.* Яңа Чишмә хәбәрләре

**ҮЗГӘРТҮ** *ф.* Икенче төрле, үзгә итү, үзгәреш кертү, башка төс бирү. *Азатның кинәт вафат булуы бөтен тормыш тәртибемне, яшәү фәлсәфәмне, тоткан мәсләгемне какшатты, гомумән, мине тәмам үзгәртте сыман.* А.Тимергалин. *Минем шушы чыбык белән бар дөньяны куалыйсым, хәяттормышны үзгәртәсем, яхшыртасым, иманга китерәсем --- килә.* А.Хәлим

**Үзгәртә бару** Акрынлап, эзлекле рәвештә үзгәртү. *Нефть кими барган саен, нефтьчеләр эш ысулларын үзгәртә барды.* Ф.Яруллин. *Ләкин акча туплау, машина алу көнен көтү аның психологиясен шундый итеп үзгәртә бара ки, машина кулга кергән көндә ул инде ярты мещанга әйләнгән була.* Р.Юныс

**Үзгәртә башлау** Үзгәртергә тотыну. *Сабит, икәүдән-икәү калып, өстәл янына кара-каршы утыргач, әкрен генә кыяфәтен, тотышын, күз карашын үзгәртә башлады ---.* А.Гыйләҗев. *Ул мәхәллә мәдрәсәсен дини тәгълимат белән дөньяви фәннәрнең органик кушылмасын хасил иткән яңа уку программасына нигезләнгән прогрессив уку йорты итеп үзгәртә башлый.* Г.Мөхәммәтшин

**Үзгәртә килү** Электән үк акрынлап үзгәртү. *Табигый ки, дөньяга карашын да, заманына, белеме һәм тәҗрибәсе артуына бәйле рәвештә, байтак үзгәртә килә [ул].* Т.Әйди. *Алда торган май бәйрәме турында уйлаганда, шушы көннең дә иҗтимагый процесслар йогынтысы астында үз асылын үзгәртә килүенә шаһитбыз.* Кызыл таң

**Үзгәртә төшү** Бераз үзгәртү. *Ул, бераз гына уйлап торгач, кинәт кыяфәтен үзгәртә төшеп: – Юк, булмый икән, җегетләр, – дип куйды.* А.Алиш

**Үзгәртеп алу** Кинәт яки беразга гына үзгәртү. *Суфия ханым сыйланырга ярата, башкалада аның бераз ризык үзгәртеп аласы килә.* Т.Әйди. *Якындагы әрәмәлектән килгән тартар тавышы гына төнге тынлыкны үзгәртеп ала.* И.Хуҗин

**Үзгәртеп бетерү** Бик нык үзгәртү; барысын да үзгәртү. *Кунак бүлмәсен тәмам үзгәртеп бетергәннәр.* З.Мәхмүди. *Сез минем җавапларны үзгәртеп бетергәнсез бит...* Ф.Сафин

**Үзгәртеп җибәрү** Көтмәгәндә, кисәк үзгәртү. *Ләкин иптәше аның хыялындагы күренешне берьюлы үзгәртеп җибәрде.* Г.Ибраһимов. *Көтелмәгән бер хәл тормышымны тамырдан үзгәртеп җибәрде.* А.Гыйләҗев

**Үзгәртеп кую** Тиз арада үзгәртү; алдан ук хәстәрен күреп үзгәртү. *Кайчакта бер көн дә кешене үзгәртеп куя...* Г.Гыйльманов. *Әйтик, каршыңда кызгылт сары төстәге кар бөртеге җемелдили, якынрак килеп карыйм дип кузгалуың була, ул инде төсен үзгәртеп куя.* З.Мурсиев

**Үзгәртеп ташлау** Кисәк тамырдан үзгәртү. *Болар инде кыска бер чорны гына түгел, дөньяның үзен тамырыннан үзгәртеп ташладылар.* Ә.Еники. *Шушы бер төн аның бөтен тормышын, язмышын тамырдан үзгәртеп ташларга җыена лабаса?!* Р.Низами

**Үзгәртеп тору** Даими, әледән-әле үзгәртү; хәзер үзгәртү. *Яшьрәк чакта, уку йортын тәмамлагач, авылга кайтырмын да шулай итәрмен, болай итәрмен, дип корган планнарны тормыш һәр җәһәттән үзгәртеп тора.* З.Хөснияр. *«Дуслык» дигән төшенчә гомер үткән саен үзенең төсмерен үзгәртеп тора.* Р.Фәйзуллин

**Үзгәртеп чыгу** Тулысынча, башыннан ахырына кадәр үзгәртү. *Шуннан соң А.Фадеев әсәрнең 25 бүлеген үзгәртеп чыкты, ун табак яңа текст өстәде ---.* Ф.Хатипов. *Алдарак әйтелгәнчә, төбәктә кытайлар белән бәрелешләр булгач, бөтен җир-су атамаларын үзгәртеп чыкканнар.* Казан утлары

**ҮЗГӘРҮ** *ф.* Үзгә булып китү; башкага, икенче төрлегә әверелү, башкачалану. *Шомлы музыка акрынлап күңелле, колакларны иркәли торган музыкага үзгәрә.* А.Гадел. *Кәеф үзгәрсә – теләк үзгәрә.* А.Хәлим

**Үзгәрә бару** Торган саен һаман үзгәрү. *Минем сизенүләрем юкка түгел иде: әнием күз алдында көннән-көн үзгәрә бара.* А.Әхмәтгалиева. *Кинәт Мөршидәнең кесә телефоны шалтырый, анда СМС хәбәр килгән, укыганда, йөзе, карашы үзгәрә бара...* А.Гадел

**Үзгәрә башлау** Үзгәрергә тотыну; үзгәрү билгеләре күренү. *Һәр икесе эчтән һәм тыштан тиз вә куәтле рәвештә үзгәрә башладылар.* Г.Ибраһимов. *Кешенең асылы үзгәрә башлаган заман бу.* З.Мәхмүди

**Үзгәрә килү** Күптәннән, акрынлап үзгәрү. *Шөкер, дип әйтергә кирәк, хәзерге вакытта безнең милли җәмгыятебездәге процесслар шул ук юнәлеш буенча үзгәрә килә.* Р.Вәлиев. *Тик «астагылар» да акрынлап үзгәрә киләләр, җае чыкканда, үзләре дә кимен куймаска өйрәнәләр.* Н.Шәрифуллин

**Үзгәрә тору** Даими, туктаусыз үзгәрү. *Заманалар үзгәрә тора...* А.Гыйләҗев. *Заман җилләре белән без дә үзгәрә торабыз.* Н.Шәрифуллин

**Үзгәрә төшү** Бераз үзгәрү. *Безнең дошманнарыбызның чыгышларына килсәк, анда манзара бераз үзгәрә төшәдер.* Г.Исхакый. *Чыннан да, соңгы вакытта Самат та үзгәрә төште шикелле.* Г.Галиева

**Үзгәреп бару** Акрын гына һәм туктаусыз үзгәрү; яңа гына үзгәрешләр күренә башлау. *Аннан соң шәһәрдәге ир затлары хәзер шактый үзгәреп бара бит.* М.Вәлиев. *Хәзер инде заманалар үзгәреп бара, ил тоташтан компьютерлы һәм телефонлы булачак, диләр.* Ф.Яхин

**Үзгәреп бетү** Бик нык үзгәрү, тулысынча үзгәрү. *Югыйсә без, тормыш үзгәрми, үзгәрми, дип лаф орабыз, баксаң, тормыш әллә кайчан алмашынып, үзгәреп беткән була, без үзебез генә тораташ катып, мүкләнеп, һаман искечә яшәп азапланабыз икән!* А.Гыйләҗев. *Яхшы якка үзгәреп беттек инде без.* Г.Тарханова

**Үзгәреп җитү** Тулысынча үзгәрү; тиешле дәрәҗәдә үзгәрү. *Министр Виктор Барсагин торак-коммуналь өлкәсенең, иң беренче чиратта, куллануччылар мәнфәгатен кайгырткан социаль юнәлештәге өлкә итеп үзгәреп җитүен ассызыклады.* Яшел Үзән

**Үзгәреп китү** Кинәт, көтмәгәндә үзгәрү. *Миңа шунысы гаҗәп тоелды: Мөсфирә апа бу юлы нигәдер бик нык үзгәреп киткән.* В.Нуруллин. *Хәлләр көтмәгәндә генә үзгәреп киткәч, берни дә эшләп булмый икән.* А.Хәлим

**Үзгәреп кую** *к.* **үзгәреп китү**. *Заманалар кискен үзгәреп куйды.* Т.Гали-

уллин. *Минзиләнең тавышы ук үзгәреп куйды.* Н.Акмал

**Үзгәреп тору** Даими, әледән-әле үзгәрү; әле, хәзер үзгәрү. *Шуның өстенә биредә һава гел үзгәреп тора: бер карыйсың, юка арестант киеме белән дә эссе, икенче карыйсың, салкыннан тешләр тешкә тими.* Г.Әпсәләмов. *Алланың рәхмәте белән дөнья гел үзгәреп тора бит.* А.Гадел

**ҮЗГӘРҮЧӘН** *с.* Еш, җиңел үзгәреп торган; тотрыксыз; алмашынучан. *Соңгы көзнең тиз үзгәрүчән һавасы шул арада бозылып та өлгергән: кояш капланып, күкнең бер ягыннан икенче ягына таба куәтле җил белән куылган соры калын болытлардан эре суык яңгыр төшә ---.* Г.Ибраһимов. *Кичке кояшның үзгәрүчән кызгылт яктысында һава диңгезендә шул оя гына хыялымны уйната...* Г.Әпсәләмов

**ҮЗГӘРҮЧӘНЛЕК** *и.* Үзгәрүчән булу сыйфаты. *Б.М. Рунин карашынча, сәнгатьченең иҗади эзләнүләре табигатькә хас булган өч фактор бәйләнешен кабатлый: төрләр хәтерен (нәселдәнлекне), үзгәрүчәнлекне, табигый сайланышны.* К.Гыйззәтов. *Телнең һәрвакыт динамикада, үсештә яшәве, система буларак, аның үзгәрүчәнлеген күрсәтә.* Татар лексикологиясе

**ҮЗГӘ́ЧӘ** *рәв.* **1.** Башкача; икенче төрле итеп. *Ул җырны син бөтенләй үзгәчә башкарасың икән.* М.Хәбибуллин. *Дөрес, Бабичның үткен каләм очына чәнчеп күтәрелгән кайбер типлары хәзер үзгәчәрәк бәяләнә, башкачарак кабул ителә.* Т.Галиуллин

**2.** *с. мәгъ.* Башка төрле; үзенчәлеге булган. *Кайбер очракларда бу сүз үзгәчәрәк мәгънәдә кулланыла.* Р.Әхмәтьянов

**Ү́ЗДИСЦИПЛИНА** *и.* Билгеле кагыйдәләргә, таләпләргә үз-үзеңне буйсындыру. *Ә каратэ үздисциплинага, тәртипкә һәм тирә-юньдәгеләргә, беренче чиратта көндәшләргә карата хөрмәткә өйрәтә.* Кама ягы

**ҮЗЕ** *а.* **1.** 1) Субъект, эштә турыдан-туры катнашучы, төп башкаручы. *Чөнки ул – үз милкен үзе урлаучы, иң соңгы кабахәт кеше!* А.Алиш. *Мамыклы кәҗәсе бар Хөснуриянең, шәлне дә үзе бәйли.* Н.Кәримова

2) Зат яки предметның берәр эшкә бәйлелеген, мөһимлеген күрсәтә. *Урман каравылчысы аңа үзе утын төйи!* А.Хәлим. *Бу баланы аның янына Ходай Тәгалә үзе җибәргән, ахры.* Г.Гыйльманов

3) Тиңдәш сыйфатлар һәм исемнәр алдыннан кабатланып килеп, мәгънәне көчәйтә. *Бакса, үзе бөкре, үзе кара йөзле, кыек авызлы, калҗайган башмак кебек әллә нинди әкәмәт борынлы борынгы әбине күреп, күңеле укшый башлый.* Ф.Яхин. *Алган бере искесеннән шәбрәк, купшырак була: телефон гына түгел, үзе фотоаппарат, үзе видеокамера, үзе диктофон, плеер, Интернет, тагын әллә ниләр...* А.Гыймадиев

4) Берәр нәрсәгә хас капма-каршы билгеләрне аерып, басым ясап әйткәндә кулланыла. *Быелгы яз әллә нинди – Үзе ярсу, үзе тын. Йөрәкләрне алгысыта Әллә шатлык, әллә моң.* Ф.Зыятдинова. *Бу нинди чәй: үзе ачы, үзе тәмле кебек.* З.Мурсиев

5) Бер үк вакытта яки бик якын вакыт аралыгында булган эш-хәрәкәтләрне аерып бирү өчен кулланыла. *Үзе ашыга, кабалана, үзе яулыгын ияге астыннан төйнәргә маташа...* А.Тимергалин. *Мирвәли үзе йөгерә, үзе һаман артына борылып карый.* Г.Гыйльманов

**2.** *и. мәгъ.* 1) Хатынның ирен атау сүзе

2) *сөйл.* Башлык, түрә. *Әллә үзе чынлап та анда юк инде?* А.Вергазов

**3.** *кис. мәгъ.* Ташлама ясап бәяләүне белдерә; аерым бер яктан караганда. *Салкын диярлек түгел үзе, әмма күшектергеч көн иде бу.* М.Маликова. *Шагыйрь түгел үзе, әмма гашыйк, Гыйшкы булгач – шагыйрь инде ул.* Ф.Зыятдинов

◊ **Үзе баш, үзе түш** Үзе теләгәнчә яшәү, эшләү һ.б.ш. турында. *[Шәвәли – хатынына:] Син биздердең балаларны. --- Тормаган кая, синең яныңда тормагайлары, – җаны теләгәнчә яши ул каласында: үзе баш, үзе түш.* Г.Ахунов. **Үзе бер бәхет** Берәр нәрсәнең аеруча әһәмиятле, рәхәт һ.б.ш. булуын белдерә. *Әйе, апа булу – үзе бер бәхет!* А.Нәҗми. **Үзе дә йөзе** Үзе әйтеп тора, үзе шаһит. **Үзенә аерым** 1) Махсус; мөстәкыйль. *Экспедиция – гәзитәне йибәрү – үзенә аерым бер фән дәрәҗәсенә килгән.* Г.Исхакый; 2) *к.* **үзенә башка**. *Бу көн кунаклар өчен дә, хуҗалар өчен дә үзенә аерым зур бәйрәмгә әйләнде.* А.Хәсәнов. **Үзенә башка** 1) Ялгыз; аерым. *Әллә һәрберенең үзенә аерым фатиры, бүлмәсе, үзенә башка казаны, самавыры, табагы, аерым өстәле бармы?* Г.Ибраһимов. *Аның иң фәггаль бүлеге шәһәрләрдә яши, сәүдәсен, һөнәрен үзенә башка халыклар белән эшли.* Г.Исхакый; 2) Үзенчәлекле, үзгә. *Бунда матурлык юк, ләкин серрият бар, җанга үзенә башка бер тәэсир бар.* Г.Ибраһимов. *Аның сүзләре дә ничектер үзенә башка, йомшак, гади, ләкин йөрәккә үтәрлек иде.* Г.Әпсәләмов. **Үзенә күрә** 1) Үзенчә; үз мөмкинлекләреннән чыгып. *Авыл да үзенә күрә килен каршыларга җыенды.* А.Нәҗми. *Тәнзилә үзенә күрә җавап та әзерләп куйган иде.* А.Гыйләҗев; 2) Билгеле бер яктан нәрсәгәдер охшаган; үзенчәлекле; бер төрле. *Ул көн үзенә күрә бер бәйрәм шикелле булды.* В.Нуруллин. *Лейтенант Даев исә Абушахманга булган игътибарын арттырды, алар арасында ниндидер үзенә күрә бер дуслык урнаша башлады.* Г.Әпсәләмов. *Аның үзенә күрә тәрәзәләре һәм чаршау шикеллерәк ачыла торган ишеге бар, ишек төбенә аяк киемен сөртү өчен камыш палас җәелгән иде.* А.Тимергалин; 3) Билгеле бер дәрәҗәдә, бер чамада. *Югыйсә кырыклап зур авылга башкала вазифаларын башкарган үзенә күрә эшлекле генә бер үзәк иде ул.* А.Хәсәнов. **Үзенә күрә түгел** Үзе турында югары фикердә булган (кеше тур.). *Үзенә күрә түгел, чәтелдәвекнең тавышы колакны яра ---.* Ш.Галиев. *Фазылҗан абый, үзенә күрә түгел, гармунның да әнә кыңгыраулысын, яшелен сайлап алды.* Р.Мөхәммәдиев. **Үзенә тарту** Күңелне җәлеп итү, ошату, яраттыру. --- *кыз Миңнулланың күңел түренә әнә шул чакта кереп утырды да гел балкып, гел үзенә тартып тора иде.* В.Нуруллин. *Бәлки, егетнең шул юашлыгы, каршы сүз әйтмәве, кешеләргә ярдәмчел булуы аны үзенә тарткандыр.* А.Вергазов. **Үзен үзе белештермәү** 1) Акылдан язу. *Ул күптәннән үзен үзе белештерми инде*; 2) Бик нык тәэсирләнүдән берәр эшне уйламыйча-нитмичә башкару. *Сәет үзен үзе белештерми алга томырылды.* В.Имамов. *Ул үзен үзе белештерми шунда таба атлады.* Р.Галиуллин. **Үзең әйткәндәй** Әңгәмәдәшнең кайчандыр әйткән фикеренә яки гомумән билгеле фикергә нигезләнеп, шуны куәтләп. *Ай-яй, Кәрим абзый, үзең әйткәндәй, бу кошларны каян җыеп бетердең?* Т.Гыйззәт. **Үзең әйтмешли** *к.* **үзең әйткәндәй**. *Үзең әйтмешли, өнгә качкан бүре баланы күп таба.* В.Имамов. *Таныш хатынга, үзең әйтмешли, ярдәм итү – джентльменлык ул.* З.Хәким. **Үзеңә кара** «Үз эшеңне үзең җайла», «үзеңчә эшлә» мәгънәсендә. *Капитан белән әрләшеп*

*алҗыган карчык, авыр сулап, үзеңә кара дигәндәй, баш какты.* И.Диндаров. *Ярый, ошамаса, үзеңә кара, ә мин танцылар вакытында рәхәтләнеп биеячәкмен.* Г.Тарханова. **Үзеңә күрә** «Яхшылыкка – яхшылык», «начарлыкка – начарлык» мәгънәсендә. *[Карак сәгатьне Сәлимгә сузып:] Мә ал, рәхәтен күр, --- минем өчен берни түгел, жәл түгел, үзеңә күрә.* Г.Гобәй. **Үзең кара** *к.* **үзеңә кара**. *Үзең кара, миннән әйтү булсын.* Г.Гыйльманов

**ҮЗЕМЧЕ** *и. сир.* **1.** Эгоист; ялгызак кеше. *Хикәяләүче индивидуалист, кайбер әсәрләрдә гарәп фәлсәфәсендәге «үземче» категориясе – «зат» сүзе белән белдерелә, ялгызак шәхес кебек тәкъдим ителә.* Д.Заһидуллина

**2.** *с. мәгъ.* Үз-үзен яратучы, эгоист; ялгызак. *Үземче кеше үлемнән куркыр.* Мәкаль

**ҮЗЕМЧЕЛЕК** *и. сир.* Эгоистлык. *Болар бар да үземчелек бит.* Ә.Еники

**ҮЗЕНЕКЕ** *а.* Предметның аның хуҗасы булган затка нисбәтләнгүен белдерә. *Гайшәнең үзенекеләр тузганнар, төпләре тишек, тик чүпрәк тыгып кына йөртеп азаплана иде.* Г.Ибраһимов. *Хөсниҗамалдан туган теге кыз үзенеке икәнен белә идеме Хәнәфи?* В.Нуруллин

◊ **Үзенекендә тору** Үз фикерен уздыру, үз фикереннән кайтмау. *Аларның күз яшьләренә, лаф оруларына карамастан, үзенекендә торды Әхәт.* З.Мәхмүди. **Үзенекен итү** Үзенчә, үзе теләгәнчә эшләү; өстенлек итү, җиңү. *Шулай да вакыт галиҗәнаплары үзенекен итте.* В.Имамов. *Гөлсия тәки үзенекен итте.* А.Нәҗми. **Үзенекен каеру** Үзенә кирәк булганча сөйләү; эшләү. *Беркатлы Бибисара яңадан үзенекен каерды: – Анысы инде, Хатирә, безнең Гөлшәһидәбез кебек үк сөйкемле сөяк булмас, – диде.* Г.Әпсәләмов. *Ләкин Гасимә гел үзенекен каерды: – Белдәбез инде андый кичектерергә ярамый торган эшләрне! – диде ул, үтергеч итеп.* В.Нуруллин. **Үзенекен сукалау** *к.* **үзенекен каеру.** *Юк, һаман үзенекен сукалый теге пәри әвәләгән нәрсә.* В.Нуруллин. *Тамараның йөзендә канәгатьсезлек билгеләре чагылып үтсә дә, Габделнур һаман үзенекен сукалый бирде.* Р.Кәрами. **Үзенекен туку** *к.* **үзенекен каеру**. *– Абыну-сөртенү – яшь тикшерүчеләр белән була торган хәл, – дип, һаман үзенекен тукыды Өлфәт.* А.Тимергалин. *Вафирә һаман үзенекен тукый.* А.Хәмзин. **Үзенеке тоту** Эпилепсия өянәге башлану. **Үзенеке үзәктә** Үзенә караган әйбер, мәсьәлә һәркем өчен беренче урында, иң әһәмиятле нәрсә булуы турында. *Һәркемнең үзенеке үзәктә шул – малае әлегә исән булып, дошманга каршы сугышып йөрүен белгән, тикниндидер сәбәп аркасында күптәннән хаты килмәгәнгә борчылган агайлар: «Алай-болай минекен очратмадыңмы анда?» – дип сорашалар.* Ф.Хуҗин. **Үзенеке үзенә җиткән** Мәшәкате күп булганга, тирә-юньгә, башкаларга игътибар итәрлек хәлдә булмаган. *Үзенеке үзенә җиткән, дигәндәй, болай да кәефе юк.* З.Хөснияр. *Халыкның борчулары болай да үзенеке үзенә җиткән.* Безнең гәҗит

**ҮЗЕННӘН-ҮЗЕ** *рәв.* Үзлегеннән, тышкы сәбәпләргә бәйсез рәвештә. *Ярымхәрби төстә, хәрби оркестр яңгыравы астында башланып киткән бу һәйкәл ачу тантанасы, ничектер үзеннән-үзе диярлек, колхозның гадәттәге эшләре белән ялганып китте.* Ф.Хөсни. *Ләкин бу критик масса үзеннән-үзе барлыкка килмәячәк.* А.Тимергалин

**ҮЗЕ́НЧӘ** *рәв.* 1) Үзе теләгәнчә. *Син аның кодрәтен онытып, үзеңчә әллә нинди планнар төзеп яткан буласың, ә ул тота да үзенчә эшли!* А.Гыйләҗев. *Бер көнне сөт ташучы җиксә, икенче көнне тирес түгүче үзенчә куалады.* В.Имамов

2) Үзенә генә хас булганча. *Теге китаплардан Берлин тирәләренең табигатен сурәтләгән урыннарны табып укып-укып карыйм, ләкин анык кына бер картина күз алдыма килми, чөнки һәр китапта үзенчә сурәтләнгән.* В.Нуруллин

3) Үзе уйлаганча; үзе белгән, күргән, булдыра алган күләмдә. *Дөрес, сугыш турында һәркем үзенчә сөйләр, чөнки һәркемнең үз язмышы бар иде...* А.Гыйләҗев. *Борынгы галим, схоластик фикер йөртү юлы белән, Алланың кодрәте чиксез киң булуын үзенчә дәлилли дә кебек.* А.Тимергалин

4) Үз телендә, үзе аңлата алганча. *Башта, ыгы-мыгы килеп, үзенчә мыгырданып ятты да [бала] ---, әллә минем өн-тавышымны ишетмисезме, күрсәтим әле үземнең кем икәнлегемне, үрлекырлы китерим әле дигәндәй, кычкырып еларга да тотынды.* С.Поварисов

**ҮЗЕНЧӘЛЕК** *и.* Кемнең яки нәрсәнең дә булса үз ишләреннән аерып торган сыйфаты, билгесе; хасият. *Безнең яшьлекнең дә, безнең мәктәп елларының да башка берәүләр татымаган, кичермәгән үзенчәлекләре бар.* А.Гыйләҗев. *Кемгә ничектер, ләкин авыл теле, шомара барган саен, үзенең үзенчәлекле төсен, тәмен, яңгырашын җуя дип уйлыйм.* А.Тимергалин

**ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ** *с.* 1) Үзенчәлеге булган; ишләреннән аерылып торган, үзенә бер төрле. *Мальта атавындагы сарайлар, гыйбадәт йортлары, хәрби ныгытмалар тирә-юньдәге кыргый ташлар белән берләшеп, гаҗәп үзенчәлекле, кырыс һәм кешелекле ысул тудыралар.* М.Юныс. *Менә кемне генә мисалга алып карама, һәркайсы ниндидер үзенчәлекле, бүтәннәрдән аермалы төскә ия: болындагы чәчәкләр, хәтта күбәләкләр дә шулай.* Ф.Яхин

2) *сөйл. ирон.* Сәер. *Ул бик үзенчәлекле кеше инде*

**ҮЗЕШЧӘН** *с.* **1.** 1) Һөнәре белән сәнгатьче булмаса да, сәнгать әсәре иҗат итә, җырлый, бии, нәфис сүз белән чыгыш ясый торган. *Ул аны «Маяк» газетасында бастырып чыгарган, үзешчән композитор Сания Әхмәтова аңа көй язган.* Ә.Исхаков. *Үзешчән җырчы*

2) Шундый кешеләр катнашында үтә торган, шулар тарафыннан оештырылган. *Диктор: «Медицина институты студентларының үзешчән концертын тапшырабыз», – диде.* Г.Әпсәләмов. *Шулай, кайчандыр хосусый йортларда оеша башлаган эреле-ваклы үзешчән түгәрәкләрдән чын профессиональ театр дәрәҗәсенә күтәрелгән, дистәләгән еллар дәвамында үз халкына тугрылыклы хезмәт иткән --- татар милли театры үз гомеренең икенче йөзьеллыгына узды.* М.Госманов

3) Һөнәри белеме булмаган, үзе өйрәнгән. *Бу хикәятем кунакларга да, үзешчән бакчачыларга да, китап укучыларга да хуш килде.* Т.Нәҗмиев

4) *куч.* Фәнни булмаган; нигезле итеп эшләнмәгән. *Дөрестер, чөнки, шөгыльләнсә дә, җитди һәм заман таләпләренә җавап бирерлек дәрәҗәдә түгел, бәлки үзешчән юнәлештәрәк фән «ясый» иде ул.* Ф.Яхин

**2.** *и. мәгъ.* Һөнәре белән сәнгатьче булмаган, әмма җырлый, бии, нәфис сүз белән чыгыш ясый торган кеше. *Аларны Эмиль Җәлилетдинов, Венера Шәрипова кебек танылган профессиональ җырчылар башкара, әлеге җырларны үзешчәннәр дә теләп җырлый.* Ф.Яруллин. *Һәммәсе дә үзешчәннәр смотрыннан башланды.* Ф.Садриев

**ҮЗЕШЧӘНЛЕК** *и.* 1) Һөнәри белеме булмаган, үзе өйрәнеп яисә үз талант

көче белән генә иҗат итү, чыгыш ясау, эшләү күренеше. *Ул – шагыйрьнең һәвәскәрлек һәм үзешчәнлек чорын үтеп, җитди проблемаларны фәлсәфи яссылыкта гәүдәләндерү сәләтенә ия шагыйрь буларак җитлегүенә дәлил.* Т.Галиуллин. *Шулай да безнең татар халкында үзешчәнлек бик көчле.* Тамаша

2) *күч.* Профессионализм булмау, осталык җитмәү күренеше, эшнең түбән сыйфатлы булуы. *Киләчәктә дә шулай дәвам итсә, әдәбиятыбызны да, сәнгатебезне дә үзешчәнлек басып китмәс микән?* Р.Вәлиев

3) *күч.* Үз белдеге белән эш итү, башбаштаклык. *Барыбыз да баскычта калабыз, ә син, Артём, авырткан аягың белән, давай, марш машинага, бернинди дә үзешчәнлек кирәк түгел безгә.* Р.Мирхәйдәров

**ҮЗИДАРӘ** *и.* 1) Нинди дә булса җәмгыятьнең, оешманың эчке эшләр белән мөстәкыйль идарә итү хокукы. *Принц Сабахетдин башлангычындагы бәгъзе яшь төрекләр котылу чарасын вилаятьләргә автономия биреп, аларга үзидарә хокукы тапшыруда күрә.* М.Хәсәнов

2) Шундый хокуклы һәм җәмгыять вәкилләре үзләре билгеләгән (югарыдан куелмаган) идарә. *Ләрия кунагын үзидарә йортына кадәр озатып куйды.* К.Булатова

**ҮЗИЗОЛЯЦИЯ** *и.* Эпидемия, пандемия чорында куркыныч, аеруча йогышлы авырулар таралуга каршы көрәшү максаты белән, хөкүмәт тарафыннан кешеләрнең урамга чыгып йөрүе, бер-берсе белән аралашуы һ.б. чикләүләргә бәйле кертелә торган чаралар режимы. *Әгәр кеше икенче кат үзизоляция режимын бозса, штраф салалар.* Шәһри Казан. *Казан Кремле Татарстанда үзизоляциядән чыгу турында игълан итте.* Ватаным Татарстан

**ҮЗИНДУКЦИЯ** *и. физ.* Электр чылбырында ток көче үзгәргәндә индукция барлыкка килү

**ҮЗЙӨРЕШЛЕ** *с.* 1) Үз тарту көче двигателе белән хәрәкәт итә торган. *Уракка төшәр алдыннан гына кайтарган өр-яңа үзйөрешле комбайнга утырмакчы иде Таһир.* А.Хәсәнов. *Соңгысында сигез йөз танк һәм үзйөрешле артиллериясе бар.* С.Поварисов

2) Кул хезмәте куймыйча, тартмыйча, төртмичә хәрәкәт итә торган. *Саша Пичугин балачагыннан, үзен хәтерли башлаганнан бирле, эчләрендәге яшерен серен ачарга тырышып, үзйөрешле уенчыкларын һәр винтигына тикле сүтеп ташлый иде.* Ә.Мушинский. *Үзйөрешле баскыч белән өскә күтәрелгәндә, башымнан әнә шундый уй сызылып үтте.* А.Әхмәтгалиева

3) Үз тарту көче белән хәрәкәт итә торган кораллары, машиналары булган. *Үзйөрешле полк*

**ҮЗКЫЙММӘТ** *и. фин.* Берәр товарны җитештерүгә киткән чыгымнар. *Базар көндәшлеге шәхси милеккә нигезләнгән хезмәт җитештерүчәнлеген без хыяллана да алмас дәрәҗәдә үстерде, товарның үзкыйммәтен түбәнәйтте һәм капиталистик илләрнең хезмәт ияләрен чагыштыргысыз мулрак тормышка алып килде.* Т.Әйди

**ҮЗЛӘНҮ** *ф. к.* **үзлеләнү**. *Камыр үзләнмәгән әле. Балчык үзләнде*

**ҮЗЛӘШТЕРЕЛЕШ** *и.* Үзләштерелү күренеше. *Көнчыгыш диалекттагы фин-угор алынмалары татар теленең урта һәм көнбатыш диалектларындагы фин-угор алынмаларыннан үтеп керү шартлары, үзләштерелеше, тел үзенчәлекләре, саны һәм сыйфаты ягыннан гына түгел, ә бәйләнештә торган тел чыганаклары белән дә аерыла.* Татар лексикологиясе

**ҮЗЛӘШТЕРЕЛҮ** *ф. төш. юн. к.* **үзләштерү**. *Ә туры һәм кыек сөйләмнәр гомумән бик җиңел үзләштерелә һәм хәтердә кала торган темалар бит инде.* В.Нуруллин. *Азагында нечкәлек билгесе (ь) булган кайбер сүзләр татар халык телендә күптән үзләштерелгәннәр һәм сингармонизм законнары буенча диярлек әйтеләләр.* Р.Әхмәтьянов

**ҮЗЛӘШТЕРҮ** *ф.* 1) Берәр юл белән чит кеше әйберен үзеңнеке итү, урлау. *Юа сатып җыелган акчаның шактый өлешен үзләштерергә өлгергән булып чыкты теге малайлар.* А.Фәләх

2) Берәр яңа яки асылда үзеңә хас булмаган үзенчәлек, сыйфат һ.б.ш. нәрсәне оту, тәкълит итеп алу; үзеңдә булдыру. *Хатын-кызлар исә, киресенчә, буыннан-буынга ир-ат сыйфатларын үзләштереп, ирдәүкә азманнар санын арттыралар.* А.Тимергалин

3) Яңа белемне өйрәнеп, төшенеп, хәтердә калдыру. *Бүтән фәннәрдән ярыйсы гына укый торган Наилә сопроматны һич кенә дә үзләштерә алмый азапланды.* В.Нуруллин. *– Ул энергияне атмосферадан ала, – диде әллә каян фәнни атамаларны үзләштергән әби.* А.Тимергалин

4) Эшкәртеп, өйрәнеп, файдалануга кертү. *Сезнең ирегез, Франциягә визиттан кайткач, хәрби флоттан демобилизацияләнгән ике йөздән артык иптәшләре белән Казахстанга чирәм җирләр үзләштерергә киткән.* А.Хәсәнов. *Ерак Космосны үзләштерү аерым дәүләтләр кулыннан килми.* А.Тимергалин

5) Нәрсәне дә булса кулланырга, эксплуатацияләргә өйрәнү, күнекмә алу. *Да, болар бар да – техниканы яхшы үзләштерә алмау бәласе, егетләр.* А.Алиш

6) *икът.* Бирелгән акчаны, средстволарны эшкә тоту. *Капитал үзләштерү*

7) *биол.* Ризыкны эшкәртеп, кирәкле нәрсәләрен организмга алу, сеңдерү. *Ашказаны теләсә нинди ризыкны үзләштерә, әмма ризык табигый булырга тиеш – җиләк-җимеш, бал, яшелчә, сөт.* Мәдәни җомга. *Исегездә тотыгыз: туену хисе ашый башлап 10 минут узганнан соң килә, ашалган ризыкның үзләштерелгәнен көтегез.* Байрак

**Үзләштерә бару** Эзлекле рәвештә, туктаусыз үзләштерү. *Сәхнә әдәбиятына хас үзенчәлекләрне Г.Исхакый үзләштерә бара.* А.Әхмәдуллин. *Женя өйрәткәнне шундук үзләштерә барды.* А.Хәсәнов

**Үзләштерә башлау** Үзләштерергә тотыну. *Тора-бара икмәкне олаулап ук үзләштерә башлады бу.* В.Нуруллин. *Алты айлык песи күзгә күренеп олыгая, ата мәчеләр холкын үзләштерә башлаган иде.* Д.Гыйсметдин

**Үзләштерә килү** Күптәннән бирле үзләштерү. *Гадел һәм дөрес итеп яшәү кагыйдәләрен кеше бөтен гомере буена үзләштерә килә.* Әдәбият

**Үзләштерә тору** Булган берсен үзләштерү; алдан ук үзләштерү. *Күпләр шулай китә инде ул: башкалар мәктәптә чалбар туздырып йөргәндә, болар, ичмасам, һөнәр үзләштерә тора.* Саба таңнары

**Үзләштерә төшү** Бераз үзләштерү. *Соңга таба урыс телен үзләштерә төшкәч, бу тәгъбир хәзерге мәгънәсен алгандыр, бәлки.* Казан утлары

**Үзләштереп алу** Тиз арада, җиңел генә үзләштерү. *Шуны гына көткән кебек, инде буын ныгытып, җитмеш җиде һөнәр үзләштереп алган Илекәй дә, хуҗасы белән хушлашып, туган якларына кайтып киткән.* Г.Гыйльманов

**Үзләштереп бару** Элекле рәвештә һәрберсен үзләштерү. *Әдәбиятның һәр темасын укып, үзләштереп барырга тырышуым да, фәннең үзен яратудан бигрәк, Хәнифә Вәлиуллловнаны хөрмәт итүгә бәйләнгән иде.* В.Нуруллин. *Неу-*

*жели инде һәр җибәргәнне үзләштереп барырга намуслары җитәр?* Ф.Хуҗин

**Үзләштереп бетерү** Тулысынча үзләштерү; барысын да үзләштерү. *Шушы ярты ел вакыт аралыгында үзенә кирәкле булган яңа күнекмәләрне үзләштереп бетерә ул.* Б.Рәхимова

**Үзләштереп җиткерү** *к.* үзләштереп бетерү. *Социализмча эш методларын әле дә булса үзләштереп җиткерә алмыйбыз...* А.Алиш

**Үзләштереп килү** Күптәннән, әзлекле рәвештә үзләштерү; әлегә кадәр үзләштерү. *Аның белән ачыктан-ачык сөйләшергә ярамаганын үзләштереп килә идем.* А.Гыйләҗев

**Үзләштереп кую** Кинәт яки тиз арада үзләштерү; алдан хәстәрен күреп үзләштерү. *Халык җәйләрен җиләк җыя торган чокырларны, көтүлекләрне дә үзләштереп куйган алар.* Безнең гәҗит

**Үзләштереп тору** Әледән-әле, даими үзләштерү; әле, хәзер үзләштерү. *Туган телебез дин өлкәсеннән философик терминнарны, логика алымнарын, абстракт фикер йөртү механизмнарын туктаусыз үзләштереп торган. М.Юныс*

**Үзләштереп яту** *сөйл. к.* **үзләштереп тору.** *Аның халкы үзе берни җитештерә алмый, тегесенең үтмәс товарын гына үзләштереп ята.* З.Хөснияр. *Бәйрәм ясыйбыз дип, акча үзләштереп ятмасыннар.* Безнең гәҗит

**ҮЗЛӘШҮ** *ф.* 1) Таныш булмаган мохиткә күнегү, ияләшү. *Юктан да кызык табып кеткелдәргә ярата торган ачык йөзле, теләсә кем белән бик тиз уртак тел таба белә торган уйнак күңелле Нәҗибәгә барысы да тиз үзләшә иде.* Т.Әйди. *Идел буендагы элек яшәгән Займище сагындырдымы, әллә бүтән сәбәпме, кисәк кенә үзләшә алмадым.* Р.Фәйзуллин

2) Күңелгә якын, үз итеп кабул ителү. *Яңа сүз башта гына чит сыман тоелырга мөмкин, тора-бара ул үзләшә, чит булып тоелмый башлый, мәгънәсе тирәнәя, киңәя, гомумиләшә, дигән фикер үткәрә автор.* Б.Рәхимова

3) Үз булып китү, чит-ят булуы сизелми башлау. *Бу төсләрнең кайберләре татардан рус теленә дә кереп үзләшкән (буланый, каурый, чалый, чубарый кебек).* А.Тимергалин

**Үзләшә бару** Торган саен яхшырак үзләшү. *Без реконструкция чорындагы әдәби хәрәкәтебездә менә бу саналган сыйфатларның көннән-көн тирәнәя, үзләшә барганын күрәбез.* М.Җәлил

**Үзләшә башлау** Үзләшергә тотыну. *Төнге кунак та үзләшә башлады, ахры, бик үк аңлаешлы булмаса да, адәми авазлар чыгарып быдырдады ---.* А.Тимергалин. *Балалар үзләшә башладылар.* Казан утлары

**Үзләшә төшү** Бераз үзләшү. *Икенчеөченче көннәргә киткәч, Мирсәет, беркадәр үзләшә төшеп, утырыр урын да тапты һәм күңеленә хуш килгән ораторларның кайбер фикерләрен куен дәфтәренә теркәп барды.* Р.Мөхәммәдиев

**Үзләшеп алу** Тиз арада үзләшү. *Шулай да бу яңа Тукай белән бик тиз үзләшеп алдым.* Г.Камал. *Бераз кызып, үзләшеп алгач, Касыйм абзыйның теле тагын да ачылды.* Казан утлары

**Үзләшеп бару** Әле үзләшү процессында булу

**Үзләшеп бетү** Тулысынча, тиешле дәрәҗәдә үзләшү. *Мин шушы җәй эчендә Рәбигалар гаиләсе белән шулхәтле үзләшеп беткән икәнмен, алар йортындагы кайгы миңа да тәэсир итте.* Г.Рәхим. *Ә менә татар телендә үзләшеп беткән, сабый чактан ук таныш, ләкин серле «магнит» сүзенә кагылмау хәерле.* А.Тимергалин

**Үзләшеп җитү** Тиешле кадәр үзләшү; тәмам үзләшү. *Тәмам ияләшеп, үзләшеп җиткәндә генә: – Иртәгә мин китәм инде, Өлфәт, – диде Сәкинә.* В.Нуруллин. *Хәлбуки ул елларда инде вакытлы матбугатта, китап-брошюраларда һәм радиода эшкәртү сүзе тәмам үзләшеп җиткән була.* А.Тимергалин

**Үзләшеп килү** Соңгы арада үзләшүгә таба бару

**Үзләшеп китү** Көтмәгәндә, тиз арада яки җае белән, әкренләп үзләшү. *Моңарчы Луизага якынаерга куркыбрак йөргән егет кинәт үзләшеп китте ---.* А.Гыйләҗев. *--- яңа сүз шулкадәр дә үзләшеп китә, аны читтән кергән дип сөйләүче уйламый да, бары тик галимнәр генә ул сүз тарихын өйрәнеп, тикшереп, аның беренчел нигезен табарга мөмкин ---.* Б.Рәхимова

**ҮЗЛЕ** *с.* Ябышучан, сыланучан, сузылучан. *Үзле балчык ябышып авырайткан тәгәрмәчләрен җылатып сөйрәп, атлылар да кузгалды.* А.Гыйләҗев. *Чиләккә дә күбрәк су түгел, үзле ләм, саз, пычрак ияреп чыга...* Г.Гыйльманов

**ҮЗЛЕГЕННӘН** *рәв.* 1) Үзеннәнүзе, тышкы сәбәпләргә бәйсез рәвештә. *Ниһаять, җансыз йөрәк беренче тапкыр үзлегеннән тибрәнеп куйды.* Г.Әпсәләмов. *Чардуган пәрдәсе күтәрелә, пьедестал үзлегеннән шуышып кереп китә.* А.Гадел

2) *биол.* Кеше катнашы, махсус чаралар кебек тышкы тәэсирдән башка, табигый рәвештә, үзеннән-үзе. *Үзлегеннән аталану*

3) Укытучы яки остаз ярдәменнән башка; махсус уку йортында укымыйча. *Эше никадәр генә авыр булмасын, егет үзлегеннән укуын ташламады.* А.Фәләх. *Ул биредә үзлегеннән рояльдә, соңрак аккордеонда уйнарга өйрәнә.* Г.Бәйрәмова

**ҮЗЛЕК** *и.* Берәр кемнең яки нәрсәнең төп сыйфаты, хасияте. *Матурлыгы һәм дәвалау үзлекләре буенча бу Һималай буйларында аңа тиңнәр юк.* А.Нәҗми. *Кемнең балчык эшенә катнашы булган, ул белә – сары балчыкның бер үзлеге бар: кислотадан болайрак киемне бетерә.* К.Кара

**ҮЗЛЕКТӘН** *рәв. сөйл. к.* **үзлегеннән**. *Бу эш курсны тирәнрәк үзләштерү, үзлектән эзләнү, өйрәнү максатларыннан чыгып оештырыла һәм башлыча гамәли дәресләргә, контроль эшләргә әзерләнү процессын үз эченә ала.* Ф.Сафиуллина

**ҮЗЛЕЛӘНҮ** *ф.* Үзлегә әйләнү. *Егет ачуыннан көрәген, дөпелдәтеп, үзеләнеп кызара башлаган мәтегә кадады, әрекмән арасыннан пыяла чирекне чыгарды һәм, башын артка аударып, әйрән эчә башлады.* Казан утлары. *Кан, куерып, үзеләнә һәм йөрәккә аны бөтен организм буенча кудыру авырлаша.* Ватаным Татарстан

**ҮЗЛЕЛЕК** *и.* Үзле булу сыйфаты; үзле булу дәрәҗәсе. *Деформацияне чамалау, металлның сыгылмалылык дәрәҗәсен, үзлелеген билгеләү, төрле үлчәмнәрне анализлау һәм максатка якынаю өчен, механика фәнендә моңа кадәр тупланган гыйлемне белү, аңа нык таяна алу кирәк.* Т.Әйди. *Бармаклар туфракның һәр төерен, дымын, көпшәклеген яисә үзлелеген тойган кебек, син дә басуыңның холкын, ни теләгәнен, нәрсәгә бай, нәрсәгә ярлы, нәрсәгә туенган, нәрсәгә сусаганлыгын бик яхшы беләсең.* Ф.Садриев

**ҮЗМАКСАТ** *и.* Кешенең үз алдына куйган төп максаты, үз эшенең, гомеренең һ.б.ш.ның төп мәгънәсе. *Язу бит үзмаксат түгел, ә халыкны мәгърифәткә өндәү, ахыр чиктә халык бәхете өчен тырышу.* М.Хуҗин. *Теге яки бу фәлсәфәгә ярашу үзмаксат була алмый бит!* И.Вәлиулла

**ҮЗМӘШГУЛЬ** *с.* **1.** Үзенә эшләүче, үз эше белән мәшгуль булган. *Күптән*

*түгел Эшмәкәрлек советы үзмәшгуль кондитерларга яңа кагыйдәләр булдырды.* Шәһри Казан. *Үзмәшгуль кеше юридик затлар белән эш итсә – табышының 6 проценты күләмендә, хосусый затлар белән эшләгәндә, табышының 4 проценты күләмендә салым түли.* Мәдәни җомга

**2.** *и. мәгъ.* Беркемне дә ялламыйча, беркемгә дә ялланмыйча, берүзе генә табыш алуга корылган эшчәнлек белән шөгыльләнүче зат; шәхси эшмәкәр. *Бүгенге көндә Татарстанда 59 меңнән артык кеше үзмәшгуль буларак теркәлгән, әлеге санны 60 меңгә җиткерү бурычы тора.* Ватаным Татарстан. *Һөнәри табыш яки --- үзмәшгульләргә салым – заказчыдан турыдан-туры акча алып, хезмәт килешүе буенча, кеше ялламыйча эшләүчеләр өчен кабул ителгән салым режимы.* Мәдәни җомга

**ҮЗМӘШГУЛЬЛЕК** *и.* Үз-үзенә эшләп, табыш алуга корылган эшчәнлек. *Минемчә, үзмәшгульлек кечкенә шөгыльгә кече бизнес дәрәҗәсенә кадәр үсеп җитү мөмкинлеге бирә.* Ватаным Татарстан

**ҮЗӨЙРӘТКЕЧ** *и.* **1.** Берәр нәрсәгә укытучыдан башка өйрәнү өчен китап, дәреслек. --- *бу үзөйрәткеч берничә тапкыр басыла ---.* Ф.Сафиуллина

**2.** *с. мәгъ.* Берәр нәрсәгә укытучыдан башка өйрәнү өчен хезмәт итә торган. *Астөшермәдә М.Иманколыйның тагын «Русча, фарсыча, төркичә үзөйрәткеч дәреслек» («Тәрҗеману русийү, фарсийү, төркийү») һәм «Касаиду латыйфә» – император Николай II гә багышлап язылган мәрсия язуы да искәртелә.* Татар әдәби теле тарихы

**ҮЗРӘ** *бәйл. иск. кит.* 1) Буена; буйлап; эченә. *Мисыр үзрә хәбәр таралды*

2) Буенча, белән. *Алланың әмере, пәйгамбәрнең сөннәте үзрә, кызыңызны углыма биреңез.* К.Насыйри

3) Турында, хакында. *Тормыш үзрә сүз*

4) Өстенә, өстендә; өсте. *Кулын тезенә куеп, тезе үзрә утырмыш.* К.Насыйри. *Әхмәтсәгыйрь дә, Хәлил дә аяк үзрә торалар.* Г.Исхакый

**ҮЗСЕНДЕРҮ** *ф.* 1) Кемгә дә булса үзенчә генә эшләргә мөмкинлек бирү, узындыру. *Аның хезмәт сөючән булуыннан минем бәхетем булды, беркайчан да аны кызганырга яки үзсендерергә туры килмәде.* Таң

2) Хисләрне уяту, күңелне үстерү, дәртләндерү. *Әйе, яңа урын, котлы урын һәр килгән кешене үзсендереп, зур эшләргә дәртләндереп җибәрә иде.* З.Мурсиев. *Аларга сөйләнгән сугыш һәм борынгы каһарманнарның өлгә булырдай батырлыклары --- хакындагы көйле кыйссалар һәм егетлеккә өндәгән шигырьләр хисләрен кузгатмый, үзләрен үзсендерми, күкрәкләрен киңәйтми калдырмады.* Ф.Яхин

**Үзсендерә төшү** Бераз үзсендерү

**Үзсендереп кую** Кинәт үзсендерү

**Үзсендереп тору** Һәрвакыт, әледәнәле үзсендерү

**Үзсендереп җибәрү** Бераз яки көтмәгәндә үзсендерү. *Дус язучылары (шаян халык) аны үзсендереп тә җибәрәләр иде.* Казан утлары

**ҮЗСЕНҮ** I *ф.* 1) Үз итү, якын итү. *Үзсенерлек тә бар шул: менә аламашалама сөйкемле генә егетләр, һәммәсе дә үз кешеләр, әнә сәкедә түшәгән, җыйнак кына, риясыз гына аларның урыннары...* Ш.Камал. *Ул безне бик үзсенә*

2) Ияләнү, күнегү; якынаю. *Ул сөйләгәндә, башкалар күңел куеп тыңлый, аның авызына карап тора иделәр. Ул үзе дә, тәмам үзсенгән рәвештә, янындагы кешеләргә һәм баракның буена сузылган сәкегә күз йөртә иде.* Ш.Камал. *Бәдери шәһәр тормышын үзсенмәде.* Г.Рәфикый

3) Чиктән тыш кылану; киреләнү

4) Дәртләнү, рухлану. *Җаныма урынны җиденче күктән бирделәрмени, үзсенеп һәм үсенеп киттем.* Ф.Яхин

**Үзсенә башлау** Үзсенергә тотыну. *Тегеләр бик үзсенә башлагач, иң элек берсенә янындагы агач кисәге белән бәрде ---.* Г.Ибраһимов

**Үзсенә төшү** Бераз үзсенү

**Үзсенеп бетү** Тулысынча, бик үзсенү

**Үзсенеп китү** Тиз арада үзсенү. *Малайның болай үзсенеп китүенә минем җаным кытыкланып китте дә, мин, әлбәттә, бик матур итеп булмагандыр инде, борылып карадым.* Г.Камал. *Ләкин шунда да бу егет миңа бик тиз үзсенеп китте, икенче көннән үк идарәгә үз бүлмәсенә кебек итеп килеп керә, минем урыннарга утыра вә ята башлады.* М.Мәһдиев. *Бәдердәге җиңү белән рухланып һәм үзсенеп китеп, мөселманнар аларны кысрыклый башларга, Мәдинәдән куарга мөмкин иделәр.* Ф.Яхин

**ҮЗСЕНҮ** II *и.* 1) Иялэшү, күнегү халәте. *[Гариф – Газизәгә:] Ләкин аңар бүгенге кебек кыюлык һәм үзсенү күрсәткәне юк иде.* Ш.Камал

2) Чамадан тыш кылану, киреләнү, узыну күренеше. *Шуның өчен дә электән әдәп һәм канәгатьлек хисен адәм баласы үзендә тәрбияләргә омтылган, комсызлыкны, үзсенүне Аллаһы Тәгалә изге китапларында кире каккан.* Ф.Яхин

**ҮЗСҮЗЛЕ** *с.* 1) Үз фикерен генә үткәрә торган, кире, тискәре. *Яшь чакта авылда Биккининнан да үзсүзле кеше юк иде. Аныңча булмаса, ул башын югалтырга әзер иде.* Ф.Садриев. *Гомер кичергән олы яшьтәге ананың, күпне күрсә дә, барыбер яшьләрчә катгый фикердә калган үзсүзле килененә андый гына боерык бирергә дә хакы бардыр.* Ф.Мөслимова

2) Сүзендә нык торучан, үз дигәненә ирешүчән, булдыручан, үҗәт. *Әнинең анасы – ерак әбинең бик үзсүзле, бөтенесен үз кулында йомарлап тотарга яратучы нык куллы үткен карчык булуын без, балалар, яхшы ук сизә идек.* Г.Бәширов

**ҮЗСҮЗЛЕЛӘНҮ** *ф.* Үзсүзлелек күрсәтү. *– Балҗан хәзер минем хатыным, – диде Амантай, үзсүзләләнеп.* Т.Әйди. *– Без язылышабыз! – дип үзсүзләләнде Самат.* Н.Акмал. *Бүген минем сине нигәдер җибәрәсем килми, Фәләх. Бер дә бүтәнгә түгел, фәкать кадереңне белгәнгә генә шулай үзсүзләләнәм.* В.Нуруллин

**Үзсүзләләнә бару** Торган саен ныграк үзсүзләләнү. *Һәр яңа сүз саен ныграк үзсүзләләнә генә барды егет.* Р.Гаязетдин. *– Талип Кәрамович үзе дә белә, – диде үзсүзләләнә барган Мидхәт.* Казан утлары

**Үзсүзләләнә бирү** Бернигә карамый үзсүзләләнү. *Шамилнең үпкә саклый белмәгәнлегеннән файдаланып, Кәрим тагын үзсүзләләнә бирде ---.* Н.Хәсәнов

**Үзсүзләләнеп китү** Көтмәгәндә яки соңгы арада үзсүзләләнү. *Җыелган арада без аның шатлануын, йомшарып китеп, елап та алуын, кайчак үзсүзләләнеп китүен күреп уйлап куябыз: аның белән бары аны чын күңелдән яраткан кеше генә яши аладыр.* Дуслык

**ҮЗСҮЗЛЕЛЕК** *и.* Үзсүзле булу; кирелек; үҗәтлек. *Егет үзен белә: холкы кырыс, үзсүзлелеге дә бар, күп нәрсәне фәкать үзенчә генә хәл итәргә ярата.* Р.Кәрами. *Тик бу кадәр үҗәтлек, горурлык, үзсүзлелек каян килә боларга?* З.Зәйнуллин

**ҮЗТӘНКЫЙТЬ** *и.* Үз эшеңә, шәхесеңә карата тәнкыйть, үз кимчелекләреңне тану, күрү. *Объективлык, үзтәнкыйть турында туктаусыз тукып*

*торабыз.* М.Юныс. *Алга киткән җәмгыятьне традицион җәмгыятьтән үзтәнкыйть аерып тора.* Р.Хәкимов

**ҮЗТӨРЛЕЛЕК** *и.* Гадәтидән аерылып тору сыйфаты. *Хәзерге заман белем бирү системасында этник үзаңлылык һәм үзтөрлелек исәпкә алынмаса, белем бирүне тулы хокуклы дип атап булмый.* Фәнни Татарстан

**ҮЗТУМА** *с.* 1) *махс.* Катнашмалардан эретеп алынган металлдан аермалы буларак, әзер кисәк килеш табылган. *Үзтума алтын*

2) *лингв.* Баштан ук телнең үзенеке булган, алынма түгел. *Ләкин үзтума исемнәр аларның кайберләрендә күбрәк һәм ныграк сакланган.* В. Хангилдин. *А.Е. Аникин һ.б. кайбер авторлар бу сүзне, шиксез үзтума тунгус-маньчжур сүзе, дип ныкышалар.* Р.Әхмәтьянов

**ҮЗУҢАЧА** *рәв. диал.* Аерым-аерым. *Кодалар югары өйгә, кодагый белән кодачалар үзуңача түбән өйгә керделәр.* Г.Бәширов

**ҮЗ-ҮЗЕ** *а.* Берәр эш-хәлнең аны башкаручыга караганын белдерә. *Һәм син, Әнисә, төсең, йөзең, рухың, үз-үзеңне тотышың белән Зөлфияне хәтерләтәсең, аңа охшагансың.* Т.Галиуллин

**ҮЗХӘРӘКӘТ** *и. филос.* Үзеннән-үзе башкарылган хәрәкәт. *Кинематик концепция карашы буенча киресенчә – табигатьтә матдә белән бәйләнештә булмаган хәрәкәт юк, матдә үзхәрәкәттә була.* Фән һәм тел

**ҮЗХӘРӘКӘТЛЕ** *с.* Үзеннән-үзе хәрәкәт итә торган. *Үзхәрәкәтле җайланма*

**ҮЗЧИР** *и.* 1) Бума, зыяндаш авыруы, эпилепсия. *Былбыл дигән сүзне ишетсә, идәнгә егылып тәгәри-тәгәри елый, үзчире тота башлый...* А.Тимергалин

2) *күч.* Котыру, ярсу, үз-үзен белештермәү. *Гыймранның үзчире кузгалган, ди, кисә-тапый, ди.* Н.Гыйматдинова

**ҮЗЧИРЛЕ** *с.* Үзчире булган, үзчирдән интегүче

**ҮЗЬЯШӘЕШ** *и.* Тышкы тәэсирләргә бәйсез яшәеш

**ҮК** *кис. к.* **ук**. *Ул беркөннәрдә үк инде, әни, мин дәү булдым ич инде, мин нишләп сабакка бармыйм инде, дип сорап утырадыр иде.* Г.Камал. *Арыш белән борай, бик үк дан булмасалар да, шулай да ачка үтерерлек үк түгел.* Г.Бәширов

**ҮКӘЛӘҮ** *ф. диал.* Ышкып юу. *Үкәлә дә үкәлә, Гомерләрем үтә лә.* Җыр

**ҮКӘЛЧӘ** *и. рус диал.* Авылны уратып алган киртә; басу киртәсе; торак пунктның чите. *Ул оч болай да котсыз, шөкәтсез иде. Үкәлчә киртәләрен ташып мичкә яктылар.* А.Гыйләҗев. *Мылтыклы солдатлар авылның ике башындагы үкәлчә капкаларына бастылар да беркемне чыгармадылар.* Т.Нәбиуллин

**ҮКЕНДЕРҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **үкенү**. *Әллә, мине сөйләтеп, серләремне сөйләгәнгә үкендерергә тырышасыңмы?* Г.Камал. *Зуфирә, ире үзен гаепле санар, ә мин аны озак гафу итмәм, ялындырырмын, үкендерермен, дип уйлаган иде.* М.Маликова

2) *з.-сыз* Үкенергә туры килү. *Искә төшә, үкендерә, үзгәртеп булмый.* Т.Миңнуллин. *Ул да үзе, мин дә үзем генә. Үкендерер, беләм, үкендерер тыңлаганга кеше сүзен генә.* Г.Корбанова

**Үкендерә башлау** Үкендерергә тотыну. *Хөршидәнең мине дөрес аңламавы да, үземнең аңа шундый нечкә нәрсәне чамасызрак ычкындырып җибәрүем дә шундук үкендерә башлады.* Г.Бәширов

**Үкендереп кую** Кинәт, шунда ук үкендерү. --- *классик әдибебез Гаяз Исхакый «эше»нең Ибраһим Нуруллин кебек зур академизм мәктәбен үткән гаять тәҗрибәле, ышанычлы, намуслы затлар кулына эләкмәве янәдән үкендереп куя.* Р. Нуруллина. *Автор Кычытканлыны ярattырырга өлгерә: авылның үткәне хакында горурланып укыйсың, умырзая аланының сөрелүе, урманнарның киселүе җанны тырнап, үкендереп куя.* Казан утлары

**Үкендереп тору** Даими, әледән-әле үкендерү; хәзер, әле үкендерү. *Бер язмышны әнә шул казадан яклый алмавы Зарифны хәзер гомер буе үкендереп торачак.* З.Мурсиев. *Әмма күңелдән һәрчак китмәгәне, үкендереп торганы да бар.* Н.Гариф

**ҮКЕНЕРЛЕК** *с.* Үкендерә торган; үкенү уята торган. *Гомерен саф килеш, пакь килеш уздырган, берәүгә дә бил бөкмәгән, берәү алдында да рияланмаган, тәлинкә тотмаган, вөҗданына хыянәт итмәгән, йөзенә кызыллык китерә торган яки үкенерлек бер генә эш тә эшләмәгән бу кешегә боларның берсе дә кирәк түгел.* Г.Әпсәләмов. *Үкенерлек юлга чыгып, гаеп-кыек ясый күрмә берүк!..* А.Гыйләҗев

**ҮКЕНЕЧ** *и.* **1.** 1) Берәр эш, вакыйга, күренешкә (югалган, эшләнми калган, башкача эшләнгән һ.б.ш.) бәйле үкенү, борчылу хисе. *Аларның күз карашында ук тел белән генә әйтеп-аңлатып булмый торган моңсулык... җирсү... үкенеч... ләгънәт... каргыш... тагын әллә ниләр бар...* Ф.Абдуллин. *Бу сүзләрдә кеше рухының кодрәтенә соклану да, үз бурычын гадел үтәүчегә рәхмәт хисләре дә, җиңел уйлар белән ялгыш юлга төшкәннәрнең чиксез үкенече дә бар иде.* М.Кәбиров

2) Үкендерерлек, үкенерлек хәл. *Үкенечен калдырырлык итмәдем, утыз бер ел рәттән тарттым.* В.Нуруллин. *Ни үкенеч, тыңлый белмәгәнбез хан торынын.* Г.Гомәр

**2.** *с. мәгъ.* Үкендерә торган, үкенерлек. *Бик үкенеч: аера бит төн якты көннән. Я, кем бар, әйтегез, үлгәч терелгән?* Г.Хәйям. *Үзәк Комитетның сәркятибе сүзен тыңламыйча ярамый, аны аяк астына салып таптасаң, анвары үкенеч хәлгә төшәреңне бел дә тор.* Казан утлары

◊ **Үкенечен калдырмау** Туган мөмкинлекләрдән файдалану; булдыра алганның барысын да эшләү. *Әле дә шунысына сөенәм: ичмаса, кулда власть барда, үкенечен калдырмадым.* Р.Зарипов. **Үкенечкә калдырмау** *к.* **үкенечен калдырмау**. *Соңыннан үчен дә кайтарды анысы, үкенечкә калдырмады.* М.Әмирханов. *Аның каравы хәллерәк авыл агайлары-апалары үкенечкә калдырмадылар, күрше шәһәрдән капчык-капчык кием-салым ише ходовой әйберләрне күп ташыдылар.* И.Диндаров. **Үкенечкә калу** Берәр мөмкинлектән, форсаттан файдалана алмау; берәр эшне вакытында тиешенчә эшләп җиткерә алмау. *Алып китим үзеңне хуш исле далабызга, үкенечкә калмасын...* М.Хәбибуллин. **Үкенечкә каршы** *кер. сүз к.* **кызганычка каршы**. *Үкенечкә каршы, Хәмидә, мин аның адресын белмим.* Т.Гыйззәт. *Мәгәр, үкенечкә каршы, язып алган кәгаземне, кайткач күпме эзләсәм дә, таба алмадым.* Ә.Еники. **Үкенечкә төшү** Бик нык үкенү. *Гүя ул бик кирәкле бер эшен оныткан да шуның өчен үкенечкә төшкән.* Ә.Гаффар

**ҮКЕНЕЧЛЕ** *с.* **1.** Үкенеч белдергән; үкенеч тулы; үкендерә торган. *Үкенечле, сагышлы уйлар Нуриянең йөрәген яндырды ---.* Р.Хәбибуллина. *Үкенечле үлем миннән дә газиземнең җылы карашын, «бәпкәм», «кызым» дигән ягымлы, йөрәкләргә җан өргән, әни кеше генә әйтә алган назлы сүзләрен ишетү бәхетен тартып алган...* А.Хәйретдинова

**2.** *рәв. мәгъ.* Үкенерлек итеп; әрәмгә, заяга. *Тиздән туар, дигән хыяллары гел үкенечле тәмамланды: һәр баласы үле*

*туды.* Г.Әдһәмова. *Сагындыра, каһәр, моңы, зары белән, Яшьлек үкенечле узса да.* В.Галиев

**ҮКЕНҮ** *ф.* 1) Эш узгач, кылган хаталарны аңлап, гаепне танып кайгыру. *Аңлагандыр да, элекке ялгышлары өчен үкенгәндер дә, дип уйлыйм.* А.Тимергалин. *Бар теләгем: яшәлмәсен иде Кылган ялгышларга үкенеп!* Ф.Зыятдинова. *Гомер буе үкенеп яшәрмен микәнни?* Р.Сальмушев

2) Уйланган эшнең барып чыкмавына борчылу. *Ә ул, табылмаган мәхәббәткә ышанып, тормышын ватып ташлагандыр да, хәзер үкенеп, үзен үзе дә күралмыйча гомер сөрәдер...* Ф.Җамалетдинова. *Их, тагын бер күреп иркенләп сөйләшеп булмады шул апа белән, дип үкенде ул.* З.Мурсиев

◊ **Үкенеп бетә алмау** Бик үкенү, үкенгән өстенә үкенү. *Ни эшлим икән, эшләр менә шулай-шулай бит дип, районнан ярдәм сорап караган идем – ник авыз ачканыма үкенеп бетә алмадым.* В.Нуруллин. *Азат сөйләгәннәрне магнитофон тасмасына язып калмавыма хәзер үкенеп бетә алмыйм.* А.Тимергалин

**Үкенә бару** Торган саен ныграк үкенү. *Хәзер инде ул кичәге дулавы-ярсуы өчен торган саен үкенә бара иде.* М.Галәү

**Үкенә башлау** Үкенергә тотыну. *Соңыннан үкенә башласаң, мин нишләрмен? Юк! Син әрәм булма, син бәхетле бул, Нюра!..* Г.Бәширов. *Тәңгәрәй буранга каршы юлга чыгуына үкенә дә башлаган иде инде.* Г.Гыйльманов

**Үкенә тору** Даими үкенү; еш үкенү. *Аннары әрәм гомергә үкенәсең. Үкенә торгач, янә дә бушка уза...* Ш.Галиев

**Үкенеп алу** Беразга гына үкенү. *Замир газ пистолетын якынрак куймаганына үкенеп алды.* Т.Галиуллин. *Хәзер Сабантуй күлмәген киеп тә булмас, дип үкенеп алган Айгөл, дусларына килеп кергәч, яраларының әллә ни булмавын күргәч кенә тынычланды.* Ф.Яхин

**Үкенеп бетү** Бик үкенү. *Зверинецка тапшыруыбызга да үкенеп беттек.* А.Хәсәнов

**Үкенеп йөрү** Озак вакытлар үкенү. *Мин гомер буе сине рәнҗеткәнгә үкенеп йөрдем.* Р.Хәбибуллина. --- *гүя шунда килеп карамаса, җанына тынычлык тапмыйча көне буе үкенеп йөрер, Юматшасы каршында ниндидер җинаять эшләр төсле.* Г.Әпсәләмов

**Үкенеп кую** Кинәт үкенү. *Моңарчы алар өендә булмавыма ихтыярсыздан үкенеп тә куйдым.* Ә.Еники. *Әмма көннәрдән бер көнне капка төбендә яхшы атка атланган, затлы киемгә киенгән Мөхәммәдьяр остазны күргәч, таш атканына үкенеп куйды.* Р.Батулла. *Боларны күңеле белән тойган, әйткән сүзен кире ала алмаячак Хәния үкенеп тә куйган иде...* А.Хәйретдинова

**Үкенеп тору** Даими, әледән-әле үкенү; әле, хәзер үкенү. – *Ризалыгын риза да, икенче билетны алуыма үкенеп торам әле, – дип әйткән, ди, ул бәндә.* Мәзәк. *Буласы булганга булган инде! Үкенеп торырга вакыт тар!* Ш.Җиһангирова

**Үкенеп яту** *сөйл. к.* **үкенеп тору**. *Шулаен шулай да, хәзер барысы өчен бергә үкенеп ятам.* А.Гыйләҗев. *Соңгы көннәрем тәмугка әйләнде, телемдә булган иң начар сүзләрне әйтәм дә, ахырдан, үз бүлмәмә кереп, елый-елый үкенеп ятам.* К.Тимбикова

**ҮКЕНҮЧӘН** *с.* Еш үкенә торган. *Усал кешеләр әүвәле гамәл кылучан, аннары үкенүчән булалар.* Ф.Яхин

**ҮКЕНҮЧӘНЛЕК** *и.* Үкенүчән булу

**ҮКЕРЕП** *рәв.* 1) Бик тиз, яхшы, күп итеп. *О-о-о, быел укроп үкереп үсә!* Р.Миңнуллин

2) Мул итеп. *Югыйсә кырык беренче елны игеннәре дә үкереп уңган иде лә.* Г.Галиева

**ҮКЕРТЕП** *рәв.* 1) Бик шәп итеп; нык итеп; бик тырышып; бөтен шартларын туры китереп. *Молодец, энем, үкертеп сату итә башладың.* Т.Гыйззәт. *Башка укучылар да Акназардан гел зарландылар: әле анысын, әле монысын үкертеп кыйнаган.* Г.Әпсәләмов. *Берзаман торып караса, Мөдәррис тә, Гәрәй дә үз ихаталарында үкертеп эшләп яталар.* М.Галиев

2) Күп итеп, мул. *Ачлык елдан соңгы елны исеңә төшер: бөтенләй чәчмәгән җирләрдә дә үкертеп уңыш урдылар.* Т.Гыйззәт

3) Бик каты, көчле итеп. *Гарифтан үкертеп самогон исе килә.* И.Шиһапов

4) Аяусыз, рәхимсез рәвештә. *Дошманны үкертеп куар көннәр килеп җитте.* Г.Әпсәләмов

**ҮКЕРТМӘ** *и.* Эре хайваннарны аулар өчен, иркәкләренең язын үкерүенә охшаш авазлар чыгара торган быргы, ау быргысы

**ҮКЕРТҮ** *ф. йөкл. юн. к.* **үкерү**. *Барышев машинасын кабызды, моторны бөтен куәтенә үкертте дә сүндерде.* М.Хуҗин. *Менә бервакыт басу капкасыннан, гармун үкертеп, өч арба егетләр килеп керде.* М.Мәһдиев

**Үкертә башлау** Үкертергә тотыну. *Капитан, машинаны кабызырга дип, стартёрны иләмсез үкертә башлаган иде инде.* Г.Кашапов. *Беркөнне кичен, бөтен кеше ял итәр вакытта, өстәме, астамы, әллә күршедәме шунда, перфоратор үкертә башладылар. Туган як*

**Үкертә бирү** Бернигә карамый үкертү. *Гармунчы бу көйне белеп бетерми икән, әмма бирешмәде, аккордеонны үкертә бирде.* М.Мәһдиев

**Үкертеп алу** Тиз генә, бер мәртәбә үкертү, беркадәр вакыт үкертү. *Миңлегали тальян гармунын үкертеп алды.* М.Мәһдиев. *Шулчак Ильяс, тракторын бер үкертеп алды да, тиреслеккә таба кереп китте.* Н.Акмал

**Үкертеп бетерү** Барысын да үкертү. *Сары чәчле марҗа дигәнем татар кызы булып чыкты, кәрәзле телефонында урыс җырларын үкертеп бетергәч, татарныкыларны тыңлап утыра башлады бу.* Кәеф ничек?

**Үкертеп җибәрү** Кинәт үкертү. *Төркемгә җитәр-җитмәс, шофёр, юри булса кирәк, моторын яман үкертеп җибәрде.* М.Хәбибуллин. *Ком өеменә җитеп, аңа утырдым, көпчәкле тракторны үкертеп тә җибәрдем.* Ф.Яхин

**Үкертеп кую** Бер тапкыр үкертү

**ҮКЕРҮ** *ф.* 1) Каты итеп кычкыру, бакыру (хайваннар тур.). *Берзаманны барча сыерлар да үкерә, әйтерсең лә алар Сәмигулланы куып җибәрергә тели.* Р.Батулла

2) Сузынкы, калын авазлар чыгару, гүләү. *Үкереп искән җил болытларны куа...* А.Алиш. *Әмма куерырга өлгергән нефть эченә торба башын батыру белән, үкереп чыккан пар шунда ук тынды.* М.Хәсәнов. *Мондый күренешләрдән мөкиббән китеп торган адәмнәр урамнарга үкереп чыккан танкларны күрми калган.* З.Хәким

3) *сөйл.* Кычкырып елау, сузып-сузып елау. *Саҗидә юк дип әйтә алмады, җавабы бугазы төбендә утырып калды, күзләренә яшь төелде, һәм ул тыела алмыйча үкереп елап җибәрде.* М.Галәү. *Иван, икенче тапкыр сугышсыз-орышсыз мәсхәрәле җиңелүне кичерә алмыйча, үкереп төннәр уздыды.* Р.Батулла

4) *сөйл.* Акыру, улау, тавышын көчәйтү. *Аның сүзен ишетергә өлгергән декан, Былтыр кыскан Шүрәле кебек, тагын да үкереп кычкырып җибәрә ---.* Ф.Яхин. *Җыелган халык та, баскынчы*

*яугирләр дә бердән үкереп аһ итте ---.* Р.Батулла

**Үкерә башлау** Үкерергә тотыну. *Моңа кадәр салмак кына эшләп яткан «райт-циклон» моторлары үкерә башладылар.* М.Юныс. *Мотор шартлап кабына һәм үкерә башлый.* И.Хуҗин

**Үкереп алу** Бер тапкыр үкерү, аз гына үкерү. *Бу җанвар тәннәргә суык йөгерерлек итеп үкереп ала да тирән ухылдап куя...* Г.Гыйльманов

**Үкереп җибәрү** Көтмәгәндә үкерү. *Кайтырга чыккач кына, арыслан кинәт туктаган, коточкыч көчле итеп үкереп җибәргән: таулар дер селкенеп киткәннәр, һавадагы кошлар җиргә төшкәннәр, башка ерткычлар кайсы кая качып беткәннәр.* А.Алиш. *Менә хәзер өйләр ишелерлек итеп яңгыратып үкереп җибәрер дә, куркудан кирпечләр ишелеп төшәр, һәм син шулар астында калып үлеп үк китәрсең сыман.* Ф.Җамалетдинова

**Үкереп кую** Кинәт бер тапкыр үкерү. *Халык диңгезе үкереп куйды.* Р.Батулла. *«Ник мине тынгысызлап йөрисең?» дигән кебек, тагын бер тапкыр үкереп куйган да, ах-ух килеп, --- түшәккә барып яткан.* Г.Гыйльманов

**Үкереп тору** Даими, әледән-әле үкерү; әле, хәзер үкерү. *Урман, каты давылда ярсыган диңгез кебек, өзлексез үкереп торды...* М.Хәсәнов. *Ул мине, идәндә тыпырдап, әтиемнең киеменә ябышып үкереп торган кызчыкны, йолкып дигәндәй үзенә тарта.* А.Әхмәтгалиева

**ҮКСӘ́ УТЫ** *и. бот.* Үксәутычалар семьялыгыннан аксыл җиләкле мәңгеяшел паразит үсемлек; *русчасы:* **омела**

**ҮКСӘ́УТЫЧАЛАР** *и. күпл. бот.* Эре, каршыдаш урнашкан яфраклы, җиләктәй җимешле, күпчелеге мәңгеяшел булган ярымпаразит куак яки үләннәр семьялыгы; *русчасы:* **омеловые**

**ҮКСЕЗ** *с.* **1.** 1) Әтисе, әнисе яки икесе дә вафат булган яки ташлап калдырган; ятим. *– Башыбызга бәла алып килмәсә генә ярар иде бу үксез бала! – дип күрсенде хуҗабикә...* Р.Батулла. *Мич янында басып тора үксез малай, Бөрешүдән кулын кулга кушкан килеш.* Р.Шәрипов

2) *күч.* Кадерсез; кирәксез; чит. *Читтәрәк үксез кебек тик бер күңелсез өй тора.* Н.Исәнбәт. *Кайдадыр бүтән җирдә, әйтик, татарның үксез туфрагы Кырымда яки Әстерханда яшәсәң, озын кышның әшәкелегеннән, пычрак көзнең хәерсезлегеннән котылып, бәхет-сәгадәт һәм рәхәтлекләр чигәрсең сыман.* Ф.Яхин

3) *күч.* Ялгыз; парсыз. *Син китәсең, йолдыз сүнәр... Ялгызлыкка ташланган Үксез ярга яшәү бирмәс яктылары көндезнең!* Р.Гаташ. *Шушы ике образдан башка берни дә юк аның теткәләнеп, җәрәхәтләнеп беткән үксез күңелендә.* Г.Гыйльманов

**2.** *и. мәгъ.* Әтисеннән, энисеннән яки икесеннән дә калган бала, ятим бала. *Үксезнең карыны туймас.* Мәкаль. *Ә Вәзирәнең күз алдында аның тәрбиясендә булган интернат үксезләре торды.* Р.Гаязетдин

**3.** *рәв. мәгъ.* Караучысыз, ятим булып. *Күрәсең, үксез үскәнгә, кечекечкенәдән миңа ияләшкәнгә шулай итә торгандыр инде...* В.Нуруллин. *Кызганып, үксез кала күз нурларым, дип кайгырам ---.* Г.Харис

**ҮКСЕЗЛЕК** *и.* Үксез булу хәле. *Шулай итеп, Майпәрвәз байлыкның да читен генә булса да күреп калган, азмы-күпме рәхәт тормышны да татыган, үксезлекнең ачы күз яшен дә эчкән, кеше ипиенең никадәр әче булуын да белгән.* Ә.Еники. *Үксезлекнең никадәр авыр булачагын әле нарасый да белми иде.* Р.Кәрами

**ҮКСҮ** *ф.* Сулкылдап елау. *Башаягы исән калуына сөенергә дә белмичә, Нәҗип өенә кайтты, җылап, шешенеп беткән Наилә аның күкрәгенә капланып бик озак үкседе.* А.Гыйләҗев. *Сәдит куанычыннан үкси иде.* А.Хәлим

**Үксеп алу** Бераз үксү. *Шулай да ул үз янына тезләнгән Айлы бикәнең шаулэсен бик тиз шәйләп алды, аның тыелып кына үксегән тавышын да аермачык ишетте.* В.Имамов. *Әнием ишекне бикләгән арада, мин, идәнгә сузылып ятып, янә аякларымны идәнгә бәрә-бәрә, берара үксеп алырга өлгерәм.* А.Әхмәтгалиева

**Үксеп бетү** Бик нык үксү. *Елап үксеп беткән тавыш белән җавап килде ---.* Г.Ибраһимов. *Мәрьям килен әнә тәмам үксеп бетте.* М.Хәбибуллин

**Үксеп җибәрү** Кинәт үкси башлау. *Мөнирәнең күзләренә яшь тулды, үксеп җибәрүдән куркып, санитарларны ашыктырды.* Г.Әпсәләмов. *Малай яңадан үксеп җибәрүдән чак тыелып калды.* А.Хәлим

**Үксеп кую** Кинәт бераз үксү. *Өчесе дә авыр сулый, өчесе дә әледән-әле үксеп куя.* Ф.Баттал. *Ага Идел... төшләрендә Үксеп куя бер сулыгып; Ярларына иңеп калган Бурлакларның моңсулыгы...* Л.Шагыйрьҗан

**Үксеп тору** Даими яки әледән-әле үксү; әле, хәзер үксү. *Кызны эзләргә мин Йөгердем, Үксеп тора иде, Көлдердем!* Ш.Галиев. *Хәдичә аның өйалды почмагында үксеп торганын күрсә дә, янына барырга кыймады, ул үзе күз яшен түгеп бетергән иде инде.* М.Маликова

**Үкси башлау** Үксергә тотыну. *Екатерина Павловна, Газинурның ике беләгеннән кысып, башын аның күкрәгенә куйды, тагын үкси башлады.* Г.Әпсәләмов. *Телефонны куюга ук, куллары өстенә капланды да Кадрия ачыргаланыпярсып үкси башлады...* В.Имамов

**ҮКЧӘ** *и.* 1) *анат.* Аяк табанының арткы өлеше. *Әллә үкчә тамыры сузылган инде, иртәнгә тубыгы шактый нык шешеп чыккан.* Х.Камалов. *Мондa әйбәт, урман сукмаклары табанга йомшак, үкчә сөякләренә артык көч төшми.* К.Кара

2) Оек, оекбаш һ.б.ш.ның шул урынны каплаган өлеше. *Ә минем носкиның үкчәсе тишек.* Т.Миңнуллин. *Кәлүшләрен салып, җылы идәнгә басса, оекларының үкчәләре тишелергә өлгергәнен, балчыклары юылып бетмәгәнен күрде.* Ф.Яхин

3) Аяк киеме олтанының астына, гадәттә, бераз биегәйтеп куела торган өлеше. *Ялан аякларына үкчәләре кыршылып, ямьшәеп беткән резин итекләр элдергән.* А.Гыйләҗев. *Гөнаһлы малай кебек башын түбән иеп, ботинкаларының әле үкчә артын, әле башын, аягын уң-сулга чалыштыра-чалыштыра карады.* Ф.Яхин

4) *тех.* Эш коралларының, төрле җайланмаларның аскы, берәр кая терәлә, таяна торган өлеше. *Шул тоткаины урнаштыргач (чалгы инде сапка утыртылган була), бер җеп-бау аласың да аның бер башын тотка төбенә басып, икенче башын чалгы үкчәсенә сузасың.* М.Мәһдиев

◊ **Үкчә астында тоту** Буйсындырып тоту. *Килен, газиз ирен үкчә астында тоту белән генә чикләнмичә, кайнанасын да йорт хезмәтчесенә әйләндереп, аңардан тәмам гүр иясе булганчы бил бөктерде.* Ш.Алпар. **Үкчә астында яшәү** Кемгәдер буйсыну. *Бәлки, әтиегез усал әни янәшәсендә үкчә астында яшәгәндер, һәм сез алай булуын теләмисездер?* Безнең гәҗит. **Үкчәгә басу** 1) Арттан куып җитеп килү; арттан калмый, ябышып диярлек йөрү. *Фашист пәме үкчәгә басып килә бит*

*безнең.* В.Нуруллин. *Шул көннән алып бүгенгә көнгә кадәр артыннан калмый үкчәсенә басып йөри.* Д.Салихов; 2) Эштәге, ярыштагы аерманы кыскарту. *Соңгы тур алдыннан ул, үзенең үкчәсенә басып килүче В. Городецкийдан ярты очко күбрәк җыеп, беренче урында була.* М.Хуҗин. **Үкчәгә тибү** *к.* **үкчәгә басу**. *Әле адашып килеп чыккан бер болыт пыскак яңгыры белән үкчәгә тибеп ала, әле сыргак буран юлчыларның яңакларын көнче хатын сыман чәбәкли.* В.Имамов. **Үкчә җиргә тимәү** Бик тиз йөгерү; йөгереп качу. *Ну шулай да икенче таң белән Врангельнең бирдек кирәгенi! Шуннан китте, шуннан китте инде, Үкчәсе дә җиргә тимәде!* Ш.Маннур. **Үкчә күтәрү** *к.* **үкчә ялтырату**. *Әйдә, үкчәң күтәр, сыз тизрәк!* Г.Камал. *Безнең аланыбыздан үкчәгезне күтәрегез тизрәк!* А.Хәсәнов. **Үкчә майлау** *к.* **үкчә ялтырату**. *Егетләр, туп-турысын гына турылап әйткәндә, сез беразга үкчәгезне майлагыз әле.* А.Алиш. *[Вил:] Бәла-казалар калкып чыкканчы үкчәне майлау – егет кеше эше!* А.Гыйләҗев. **Үкчәсенә тай басмаган** Дөнья күрмәгән, тормышны татымаган, тәҗрибәсез. **Үкчә ялау** Ялагайлану. *– Син үкчәләрен ялаган хуҗаларың аны, кызганычка каршы, производствода була торган гадәти хәл итеп кенә санаячаклар, – дип кисәтте.* А.Хәсәнов. **Үкчә ялтырату** Тиз арада юк булу, качу, таю, сызу. *«Тай моннан, үкчәңне ялтырат, сыпырт!» – дисең инде?* А.Гыйләҗев. *Яхшы, исән-имин чакта бу аланнан тизрәк ычкынырга, үкчәңне ялтыратырга кирәк.* А.Хәсәнов

**ҮКЧӘЛЕ** *с.* 1) Олтанының астында үкчәсе булган. *Аның башында зәңгәр кәләпүш, өстендә җиңел чапан, аягында үкчәле яшел читек иде.* Г.Бәширов. *Ботинкасы биек үкчәле, ялт та йолт килә, әллә апасының кершәнен сылаган инде...* А.Тимергалин

2) Үкчәсе биек булган. *Көне буе үкчәле туфли киеп йөрмәгез!*

**ҮКЧӘСЕЗ** *с.* 1) Олтанының астына үкчә куелмаган; тигез табанлы. *Мәсәлән, әнием бервакытта да йөзен ирләрдән яшерми, шулай ук абыстайлар шикелле укалы камзул, үкчәсез читекләр дә киеп йөрми.* Ә.Еники. *Аңарга ияргән Галиуллага халаты астыннан чыгып торган кальсон балакларыннан, аларны бәйләгән ак тасма баулардан, госпитальнең үкчәсез чүәкләреннән уңайсыз булып китте.* З.Зәйнуллин

2) Гадәти үкчәле, үкчәсе артык биек булмаган. *Үкчәсез туфли*

**ҮЛӘБӘТ** *и. диал.* 1) Үлгән хайван гәүдәсе, үләксә

2) *күч.* Бик бетешкән, көчсезләнгән, зәгыйфьләнгән, үләр дәрәҗәгә җиткән кеше яки терлек

**ҮЛӘКСӘ** *и.* **1.** 1) Хайван, кош мәете, шуларның үле гәүдәсе. *Үләксә исен козгын алдан сизәр.* Мәкаль. *Авыл халкы нишләргә белмичә хафада калганда, комиссия котырган малларны атарга, үләксәләрен яндырырга боерды.* А.Гыйләҗев

2) *кимс.* Кеше мәете, җәсәде. *Галим карт үләксәсе бу үлекләр дөньясына тагы бер кеше арттыру гына иде.* Г.Ибраһимов

3) *күч. кимс.* Нык ябык, хәлсез кеше. *Алып атыгыз шул карчыкны, үләксәне!* Г.Каюмов. *Ничава, бүген шәп үгез булып йөрсә дә, иртәгә үләксә ул.* В.Имамов. *Менә миңа кара – бер царапина да юк. Ә бу үләксәнең көннәре күп калмаган.* Г.Гыйльманов

4) *күч. тирг.* Начар, чирканыч, кирәксез кеше. *Ах, үләксәләр! Шушы көнгә кадәр мин аларның начарлыкларын ничек сизмәдем икән соң?* Т.Гыйззәт. *[Айгөл:] Кеше исәбенә кереп сөйләшеп тормасаңчы. Мирдән калган үләксә!* Д.Салихов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Үлгән. *Карга киткән дә, бер үләксә сарык күреп, үләксә ашарга ябышкан, ди.* Легенда

2) *күч.* Бик ябык, шыр сөяккә калган. *Үләксә алаша җигеп чыксаң, бу кеше кыз урлап йөри дип бер генә мент та уйламас.* З.Мурсиев

◊ **Үләксәгә калу** Бик нык ябыгу, хәлсезләнү. *Андагы поляклар, рус кешесен кызгансалар да, бригадаларыннан күчерүне сорыйлар: үләксәгә калган әсир бригаданы артка сөйри.* С.Ибраһимова

**ҮЛӘКСӘ АКЧАРЛАГЫ** *и. зоол.* Үләксә акчарлакчалар семьялыгыннан тундра, төньяк диңгезләр яр буенда, утрауларда яши торган карасу төстәге кош; *русчасы:* **поморник**. *Җәен яр буйларында бакланнарны, үләксә акчарлакларын очратырга мөмкин.* Материклар һәм океаннар географиясе

**ҮЛӘКСӘ́АШАР** *и. зоол.* Үләксәашар коңгызлар семьялыгыннан үләксә белән тукланучы карасу төстәге эре коңгыз

**ҮЛӘКСӘ́АШАР КОҢГЫЗЛАР** *и. күпл. зоол.* Катыканатлылар отрядыннан, күпчелеге табигатьтәге органик калдыкларны – үләксә, черек гөмбә, үсемлекләр һ.б.ны үзләштерә торган коңгызлар семьялыгы; *русчасы:* **мертвоеды**. *Үләксәашар коңгызлар үлгән вак хайваннарны күмеп куялар һәм аларның таркала торган калдыклары белән тукланып, туфракның мәетләрдән арынуын, анда черемә туплануын тәэмин итәләр.* Биология

**ҮЛӘКСӘ́ БАЗЫ** *и. к.* **үләксәлек**. *Ике үләксә базын тутырырлык сыер харап булган.* Безнең гәҗит

**ҮЛӘКСӘ́ КОЗГЫНЫ** *и. зоол.* Карчыгачалар семьялыгыннан шәрә башлы, томшыгы һәм арткы очлыклары җете сары, гәүдәсе, канатлары аксыл төстәге үләксә белән туклана торган кош; *русчасы:* **стервятник**. *Ул да булмый, кайдандыр үләксә козгыны очып килеп чыга.* Г.Әпсәләмов. *Я Хода, нәрсәгә куана бу? Үләксә козгыны диярсең.* Н.Әхмәдиев. *Таң беленер-беленмәс, яугирләр каты йокыда чакта, әрдәнәләп өелгән мәетләр өстендә үләксә козгыннарының мәхшәр туе башлана.* Р.Батулла

**ҮЛӘКСӘЛЕК** *и.* Үләксәләр илтеп ташлау өчен билгеләнгән яки махсус казылган чокыр. *Сиңа карата андый хөсетлек кылган холоп бүгеннән җәзасын табар – башы үләксәлектә черер.* Ф.Латыйфи. *Аучылык трофейларының файдаланылмаган калдыкларын биологик калдыкларны җыю, утильләштерү һәм юкка чыгаруның ветеринария-санитария кагыйдәләре нигезендә моның өчен махсус билгеләнгән урыннарда (үләксәлекләрдә) юк итәргә, андыйлар булмаганда яндырырга кирәк.* Биектау хәбәрләре

**ҮЛӘКСӘ́ ЧОКЫРЫ** *и. к.* **үләксәлек**. --- *март аенда төннәрен урамга чыксаң, үләксә чокыры ягыннан бүреләр улаганы ишетелә иде.* Г.Ахунов

**ҮЛӘМӘТ** *и. сир.* **1.** Көчсез, зәгыйфь, авыру кеше, хайван. *– Менә шулай, Нәзир туган, мондый үләмәт хәлендә яшәп булмый, – диде [Муса].* Ш.Маннур. *Аның ише үләмәт. Чирләп ята әнә.* Н.Фәттах

**2.** *с. мәгъ.* 1) Көчсез, зәгыйфь, бетешкән. *Чеп-чеп-чеп, и, үләмәт нәмәрсә, тагын болдырдагы таска кереп чыккансың бугай, лычма булгансың...* А.Әхмәтгалиева

2) Начар, түбән дәрәҗәдәге. *Икътисады булса үләмәт, сугыш белән көн күрә дәүләт.* Безнең гәҗит

**ҮЛӘН** *и.* **1.** 1) Агач һәм куактан аермалы буларак, яшел йомшак сабаклы бер яки күпьеллык үсемлек. *Ә зиратта мул булып үлән калкынган! Сусыл*

*сабаклы әнисләр чәчәк аткан.* А.Гыйләҗев. *Кая карама яшеллек, биек үләннәр, хуш исле чәчкәләр.* А.Хәлим

2) *куч.* Иттән аермалы буларак, туклыксыз яшелчә һ.б.ш. ризык. *Ашатуларының рәте булмады. Үлән ашап тукланып буламыни?*

**2.** *с. мәгъ.* 1) Шундый үсемлекләрдән ясалган, шундый төр үсемлекләрдән гыйбарәт. *Үлән азык әзерләү*

2) *куч.* Яшелчәдән гыйбарәт, шуның кебек туклыксыз. *Көне буе сарык артыннан чабып арыган егетнең азыкка булган ихтыяҗын кыяр-помидор ише үлән азыклар гына канәгатьләндерми башлагач, әкренләп, башта майсыз, аннан майлырак та булган ит ашала башлый.* И.Кашфразыев

◊ **Үлән астыннан ут йөртү** Яшерен эш итү; астыртын эшләү. *Астыртын үлән астыннан ут йөртә.* Мәкаль. *Маташмаңыз үлән астыннан ут йөртеп, Халык ирке нигезенә утлар төртеп, Дошманыңыз капкасына дегет сөртеп...* Г.Камал

**ҮЛӘ́Н БЕТЕ** *и. к.* **гөблә**. *Аның сүзләрен, беренче булып, кырмыска оясы янындагы агачта утырган гөблә – үлән бете ишетте.* К.Тәхау. *Үлән бете бакчадагы үсемлекләргә зур зыян китерә.* Яңа тормыш

**ҮЛӘНЛЕ** *с.* 1) Үлән үскән, үлән белән капланган. *[Сарсымбай:] Молдакәм, казакъның бер сүзе бар: үләнле җирдә мал симерер, үлекле җирдә мулла симерер диләр, моны ишеткәнең бармы? – диде.* Г.Ибраһимов. *Күкбаш артыннан ук көмеш сулы тугайлар янындагы уйдыкларда көпшәләр үсеп чыга, хәтфә үләнле, кояшлы аланнарда балтырганнар өлгерә.* А.Гыйләҗев

2) Үләннән гыйбарәт, үлән кушып әзерләнгән. *Үләнле салат*

**ҮЛӘНЛЕК** *и.* Төрле үлән үскән, куе үлән белән капланган җир. *Биек таш койма белән чолганган киң һәм озын бу ишегалды, таш белән түшәлгәнлегенә карамыйча, ямь-яшел үләнлеккә әйләнгән ---.* Ф.Әмирхан. *Газоннардагы мул үләнлек тәмам изелеп бетте.* М.Галиев

**ҮЛӘ́Н-СҮЛӘН** *җый. и.* Төрле үләннәр (ешрак вак яки дарулы үләннәр тур.). *Район үзәгеннән килеп киткән табибларның да, үлән-сүлән белән дәвалаучы белемче карчыкларның да шифасы тиде, ахрысы, чирне җиңеп, апа аякка басты.* М.Галиев

**ҮЛӘНЧЕ** *и.* Дару үләннәре җыючы һәм шулар белән дәвалаучы кеше. *Белгечлеге буенча химик һәм биолог Римма апа – тәҗрибәле үләнче. Әледән-әле йөткергәләп алуымны күреп, ул миңа могҗизалы бер «дару» эшләргә өйрәтте.* Шәһри Казан

**ҮЛӘНЧЕЛ** *с. махс.* Үлән булып үсә торган. *Агачлардан дымлы урыннарда үсә торган зирекне, үләнчел үсемлекләрдән һәртөрле күрәннәрне, эт тигәнәгеен --- күрсәтергә мөмкин.* Ботаника

**ҮЛӘ́Н ЧЫПЧЫГЫ** *и. зоол.* Юлчы солы чыпчыклары семьялыгыннан төньякта яши торган кош; *русчасы:* **пуночка**

**ҮЛӘ́Н ШӨЛДИЕ** *и. зоол.* Бекасчалар семьялыгыннан озын тар томшыклы, уйсу җирләрдә, тайга баткаклыкларында яшәүче кош; *русчасы:* **поручейник**. *Үлән шөлдие Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән*

**ҮЛӘҢ** *и. фольк. этн.* Казакларда һәм алар белән тыгыз аралашып яшәгән татарларның кайбер этник төркемнәренә хас фольклор жанры: үзенчәлекле рифма төзелеше һәм үлчәме белән аерылып торган, гадәттә думбрага җырлана торган сюжетлы озын җыр. --- *кушчы казак, озын кәрван буенча бер баштан икенче башка йөгерә-йөгерә дөяләрне куып бушаган арада, моңлы тавыш белән сузып-сузып кына үләң әйтергә керешә.* М.Галәү. *Кымыз эчеп, кубыз уйнап бик күңелле генә сөйләшеп, үләң әйтеп утыралар болар.* Р.Батулла

**ҮЛӘҢЧЕ** *и.* Үләң әйтүче, үләң чыгаручы. --- *әлеге җырны кем теләсә шул башкармаган, ә тәҗрибәле җыручылар – үләңчеләр, үзенә күрә профессиональ яр-ярчылар әйткән.* М.Госманов

**ҮЛӘТ** *и.* 1) Гадәттә, берәр йогышлы авыруның киң таралуы сәбәпле, халыкның, мал-туарның күпләп үлү күренеше; эпидемия. --- *җәй башында көтү кырга чыккач, җирне капка кебек итеп казып, һәммә хайванны шул җирдән үткәзәләр, җәй буенча хайванга үләт тимәсен дип.* К.Насыйри. *Ул чакларда әле бер, әле икенче авылда ваба үләте чыккан.* Г.Әпсәләмов

2) *куч.* Кешеләрнең күпләп үлүенә китерә торган афәт; кыргын. *Һәйкәлдә исемнәре язылган кешеләр безнең кадерле туганнарыбыз, дусларыбыз, күршеләребез, алар дөньяны фашист үләтеннән коткарды.* З.Мурсиев

3) *сөйл. тирг.* Берәү тарафыннан начар, юньсез дип бәяләнгән кеше, шундый кешегә карата әйтелгән тиргәү сүзе. *Комсомол җыелышына барган идем, анда да теге үләтне уйлап утырам бит!..* А.Гыйләҗев. *Нәрсәләр мыгырдап утырган була бит, үләт!* З.Хәким

◊ **Үләт еккыры** *к.* **үләт кыргыры**. *Әй-әй, таза бу, үләт еккыры!* Г.Бәширов. **Үләт кыргыры** 1) Кемне дә булса ачуланып, сүгеп яки начар теләк белән әйтелә торган каргыш; 2) Ымлык буларак кулланылып, үкенү, җиңелчә ачулану, соклану һ.б.ш.ны белдерә. *Әһә, үләт кыргыры нәрсә! Күптән ятасың, ахры, бөтенләй тутыгып беткәнсең икән!..* Ә Еники. *Их, тиятере мәхәббәт турында ди бит. Үләт кыргыры, күрә алмый калам инде.* Ф.Яруллин. **Үләт себергере** *к.* **үләт кыргыры**. *Һи, үләт себергерләре!* Г.Бәширов. **Үләт ялагыры** *к.* **үләт кыргыры**. *На, үләт ялагыры! Чистый ялкаулыкка чыктың, мөртәт!* Г.Ахунов

**ҮЛӘ́Т БАЗЫ** *и. к.* **үләксәлек**. *Әле ярый корылык ел, килеп, барча үләксәне, үләт базларын яндырып бетергән, ди.* В.Имамов. *Атны шунда, Мамадыштан ерак түгел үләт базында җирләдек.* З.Хәким

**ҮЛӘ́Т БӨРКЕТЕ** *и. зоол.* Карчыгачалар семьялыгыннан үләксә, йомран, кошлар белән туклана торган, киң канатлы, кәкре томшыклы зур ерткыч кош; *русчасы:* **орёл-могильник**

**ҮЛӘТЛЕ** *с.* Үләт булган; эпидемия кичергән; күпләп үлемгә китерә торган авыру йоктырган. *Германиядә, мәсәлән, аэропортларда, автобаннарда барлык йөкләрне җентекләп тикшерә башлаганнар: нимесләр илгә үләтле тобәкләрдән законсыз рәвештә кош ите керер дип курка.* Татарстан яшьләре

**ҮЛӘ́Т ЧОКЫРЫ** *и. к.* **үләксәлек**. *Авылның чүп-чары, иске-москысы, мал үләксәсе ташлана торгач, үләт чокырына әйләнеп, тирә-ягында урман биеклегендәге кычыткан, ат кузгалагы һәм тас кадәр әрекмәннәр үсә анда.* А.Хәлим

**ҮЛӘ́-ҮЛӘ** *рәв.* 1) Бер-бер артлы үлеп. *Без анадан өчәү тудык, үлә-үлә, бишкә калдык.* Мәкаль

2) *куч.* Күп көч түгеп, зур авырлыклар кичереп, көч-хәл белән. *Авылга кайткан саен, пенсия алып та, үлә-үлә эшләүче пенсионерларны күрәм дә уйлап куям: мал, дөнья артыннан куганчы, тәрбияле оныклар --- калдыру дөрес булмасмы?* Г.Нурулла

**ҮЛЕ́** *с.* **1.** 1) Үлгән, яшәүдән туктаган, тереклеге беткән, җансыз. *Үле бүренең башы белән Тере атаңны куркытма,*

*Токымыңны орасы!* Дастан. *Шул төнне ул үле бала тапты*. Р.Батулла

2) Корыган, кипкән, шиңгән. *Багана чери – җир белән тере багланышы юк, җиргә кендеге тоташмаган үле агач инде ул.* Ш.Галиев

3) *күч.* Тоник, салкын, җылылыгы булмаган, бернинди хис чагылдырмаган. *Үзе шомлы, үзе серле яктылык гаҗәеп үз һәм коточкыч ят булып, үле күздәй карап тора күшегеп ---.* Р.Харис. *Әмма, авызын ачып сүз ката алса да, аның карашлары үле ---.* Г.Гыйльманов

4) *күч.* Тереклек, яшәү билгеләре чагылмый торган. *Үле урманга шунда ук җан керде.* Җ.Тәрҗеманов. *Ул планетада үле шәһәрләр, эре индустрия объектлары әкрен генә таркалып ята ---.* З.Мифтахов // Тереклек юкка чыгарылган. *Озак, бик озак барды алар кипкән, актарылып ташланган үле җир буйлап.* Ф.Бәйрәмова // Хәрәкәтсез, өнсез, тереклек билгеләрен тәмам югалткан сыман. *Дулкыннарның актык сугылуына мол чыдамады. Һәм җансыз булып, диңгез төбенә, үле дулкыннар катына шаулап төшеп китте.* Г.Коләхмәтов. *Кара инде бу каланы, көрткә чумып, карга-саесканнар тавышына эреп, үле йокыга киткән.* Ф.Яхин

5) Эшләүдән туктаган. *Телефон үле иде.* М.Кәбиров

6) Табыш, файда китерми, үсем бирми торган. *Чамадан тыш чыгымнарга корылган, бизнес һәм культура үсешенә ярдәм итми торган биналар – үле капитал.* Р.Хәкимов

7) Берәр төрле активлык, эшчәнлек туктап торган яки кимегән. *Торак бәяләре базарында үле сезон.* Кызыл таң

8) Кулланылмый, эшкә ярамый торган, кирәксез. *Без үле фактлар арасында гомер итәбез, ә алар символлар һәм билгеләр арасында яшиләр.* И.Вәлиулла

9) Тәэсир итми, нәтиҗә бирми торган, файдасы булмаган. *Сәгать төрле очраклы кунаклар өчен дип тоткан бер тәрәзәле почмак бүлмәдә эленеп тора һәм күптәннән йөрмәгәнгә охшый, чөнки эленеше үк туры түгел – ул үле бер декорация генә булып калган.* А.Тимергалин

10) *күч.* Бернинди тавыш та ишетелмәгән, абсолют. *Өч сәгатьтән соң таулар арасындагы үле тынлык әрнүле ыңгырашулар, җил улаулары белән алмашынды.* Г.Әпсәләмов

11) *махс.* Берәр тәэсир өчен ирешелгесез; игътибар, караш, берәр нәрсәнең тәэсире тышында. *Хәзер ул танкның пуляларры тия алмый торган үле арада иде.* Г.Әпсәләмов

12) *күч.* Матурлыгын, ачыклыгын югалткан, сулган, тоныкланган. *Ул баягыдан да шыксыз, үле төсләр сеңгән казна йортының ярым караңгы коридорына чыкты.* А.Гыйләҗев

13) *күч.* Гамәлдән чыккан, кулланылудан туктаган. *XX гасырда үле телләр исемлеге шактый «баеды».* А.Тимергалин. *Тел төзелешен өйрәнгәндә, галимнәр продуктив кушымчалар, продуктивлыгын югалткан кушымчалар, үле кушымчалар дигән терминнар белән дә эш итәләр.* Ф.Хисамова

14) *күч.* Җансыз табигатькә караган. *Оста рәссам үле ташка хәрәкәт бүләк иткән – берне генә түгел, әллә ничә хәрәкәт...* А.Тимергалин. *Бу җиһанга үле материя итеп карау – үзе бер гакылсызлык.* З.Мәхмүди

15) *күч.* Агулы, үтерә торган. *Абелхәятның капма-каршысы – үле су.* А.Тимергалин

**2.** *и. мәгъ.* 1) Мәет; үлгән кеше. *Авыл урамы үле чыккан йорттай бушап калыр.* М.Маликова

2) Үлү очрагы; үлем. *Ә бер китүеннән ул кайтмады, үле хәбәре килде.* Н.Әхмәдиев

**3.** *рәв. мәгъ.* Үтә, бик нык. *Тик йөрәкне алдым кулга, Ул әйләнгән җансыз бозга. Ул сап-салкын, үле салкын, Вулкан ата.* Б.Ибраһим

◊ **Үле дисәң гүрдә юк, тере дисәң санда юк** Булдыксыз кеше. **Үле җаннар** Чынлыкта булмаган яки үлгән, кәгазьдә ялган рәвештә бар дип күрсәтелгән кешеләр. – *Ике-өч ел элек үк башка шәһәрләргә киткән «үле җаннар» ник бүген дә сезнең оешмада исәптә тора? – дип, сәлам дә бирмичә ишектән атылып кергән ярсу кызны күргәч, киң өстәл артында утырган беренче секретарь аны күн тышлы кәнәфиеннән кузгалып каршылады.* В.Имамов. **Үле нокта** Эшнең кузгалмыйча, башлана алмыйча, тик тору хәле. *Ләкин һаман саен сүздә генә калу килешми, күмәкләшеп, оешып, әртилебез белән тотынып, бу юлы эшне «үле ноктасыннан» кузгатып җибәрик, көнчел ут күршеләребез дә, уңай нәтиҗәсен күреп, муен артларын кашырлык булсын.* А.Тимергалин

**ҮЛЕБАШ** *и. зоол.* Балкаракчалар семьялыгыннан күкрәгендә баш сөяген хәтерләткән рәсеме булган эре күбәләк

**ҮЛЕК** I *и.* **1.** Үлгән кеше гәүдәсе, мәет. *Туйга да шул әтәч башын өзәләр, үлек ашына да.* Мәкаль. *Белерсең син боларның мәхшәре дип, Бу бозларны – үлекләр гаскәре дип.* Г.Тукай. *Ә Назимов караңгы төшкәнче үлекләр арасында ятты, аннары торып, күзе караган якка китте.* Г.Әпсәләмов

2) *күч.* Хәрәкәтсез, җансыз нәрсә

**2.** *с. мәгъ.* 1) Үлгән, тереклеге югалган, җансыз. *Гашыйклыктан онытты ул үлек шаһзадәләрне дә.* Г.Тукай. *Мин шул урманнарга карыйм да алар өстендә Латыйф абзыйның үлек гәүдәсен күрәм.* Ә.Еники

2) *күч.* Тиешле, уңай сыйфатларга ия булмаган. *Кайгы белмәс, дөнья җимерелгәндә дә хәсрәт чикмәс үлек йөрәкләр барлыгын ишетәбез.* Г.Ибраһимов

3) *күч.* Җансыз, күңелсез; буш. *Ләкин тора-бара очы-кырые күренмәгән үлек дала аны борчый, шомландыра башлады.* Ә.Еники

4) Тоник, тәэсирсез, берни чагылдырмаган; хәлсез. – *Мулла, аз гына да борчылмыйча, шул элекке үлек, тоник сүзләре белән җавап бирде.* Г.Ибраһимов. *Кәгазь битенә әллә нинди салкын, үлек юллар гына тезелә.* Г.Әпсәләмов

**3.** *рәв. мәгъ.* Үле хәлдә. *Гүя минем алдымда Нәфисә түгел, Кадрия ята... юк, икәве дә үлек яталар, имеш.* Г.Кутуй. *Судмедэксперт хезмәткәрләре бала үлек туган димәкче.* Кызыл таң

◊ **Үлек ашаучы** Бик тә саран, кысмыр кеше. **Үлек йокысы белән йоклау** *к.* **үлек кебек йоклау**. *Йортта аңа бер генә ишек тә, хәтта ата-анасы ишеге дә ачылмады, барысы да үлек йокысы белән йоклыйлар иде...* Ф.Бәйрәмова. *Катының, төн ката шигер-мигер язып, иртән үлек йокысы белән йоклый ул!* Н.Гыйматдинова. **Үлеккә сөлек салгандай** Эш үткәч, файдасызга ярдәм күрсәткән булып кылану. **Үлек кебек агарыну** Нык курку, кот алыну. *Карт хәлфә, бу хатны хәзрәткә укыгач, үлек кебек агарынды, теле тотлыкты ---.* Г.Ибраһимов. *--- бомбёжка вакытында үлек кебек агарындыгыз.* Г.Әпсәләмов. **Үлек кебек йоклау** Тирән йокыга талу; бик каты йоклау. *--- үлек кебек йоклаганмын, хәтта бер генә тапкыр борылмаганмын да.* Ә.Еники. *Фәүзия үзенең бүген төнлә үлек кебек йоклавына аптырап уянды.* Т.Гарипова. **Үлекләрнең фатихасы, терекләрнең догасы белән** Бакыйлыкка күчкән һәм исәннәрдән яхшы кешеләрнең теләктәшлеге белән эшләнгән. **Үлек төсе иңү** *к.* **үлек төсе керү**. **Үлек төсе керү** Бик нык ага-

рыну, төссезләнү. *Аңа [Сөен-бикәгә] үлек төсе кергән иде.* Һ.Атласи. *Җыерчыкланып беткән какча йөзенә үлек төсе кергән,ябыккан гәүдәсе бары тире дә сөяк.* Г.Хөсәенов. **Үлек чыккан төсле (кебек, шикелле)** Кайгылы, хәсрәт тулы авыр тынлык, күңелсезлек. *Барысы да үзләрен үлек чыккандагы кебек кыен, уңайсыз сизделәр.* Н.Фәттах. **Үлек чырае чыгу** *к.* **үлек төсе керү**

**ҮЛЕК** II *и.* Бактерияләр тәэсирендә организм тукымасы ялкынсыну сәбәпле барлыкка килә торган саргылт яшел төстәге, начар исле, куе сыеклык; эрен. *Яралары, озак бәйләнми, үлек белән саркып яткач, аны яман шеш баса ...* А.Хәлим. *Операциядән соң да яра озак төзәлмәде, үлек килеп торды, бинтны алмаштырып өлгерешле булмады.* А.Хәсәнов

**ҮЛЕКЛӘ́Ү** *ф.* Тән тукымасы яраланып үлек (II) җыю, эренләү. *Күпереп шешкән беләгә хөрмә төсле каракучкылланып ялтырый, теш эзенең берсе үлекләгән иде.* Ф.Садриев. *Ә минем, муены аска килгәре, башы беткере аппендикс һаман үлекли бит әле, җөй дә ябылмый.* А.Хәсәнов

**Үлекләп бету** Бик нык үлекләү. *[Балаларның] --- иң кечкенәсе бетчәләп, үлекләп беткән арык бармагын суырырга тотынды.* М.Галәү. *Алар [гарип балыклар] дөм сукыр, күзләре бөтенләй юк, ә тәннәре тишелеп, үлекләп беткән, уч-уч йолкынып, кубып чыккан иде.* Ф.Бәйрәмова

**Үлекләп йөрү** Озак вакытлар үлекләү. *Эт тешләгән урындагы яралар һаман үлекләп йөри, бөтен балтырым гөбедәй булып шешкән.* С.Таҗетдинов

**Үлекләп килү** Аз-азлап, акрынлап үлекләү; күптәннән үлекләү. *Палатада бер кеше бар иде, тездән аягын кискәннәр, ә өске өлеше каралып, үлекләп килә, чери башлаган, кыскасы.* Авыл офыклары

**Үлекләп тору** Озак үлекләү; әле, хәзер үлекләү; бераз үлекләү. *Аягының балтыр сөяге авырта, берничә урыннан тишелеп, үлекләп тә тора иде.* В.Нуруллин. *[Искәндәрнең] чырае апак, кулының киселгән җире әле һаман сызлап, үлекләп тора.* З.Мәһмүди

**Үлекли башлау** Үлекләргә тотыну. *Шул яра үлекли башлаган да, Мстислав, өенә дә кайтып җитәргә өлгермичә, яман шешенеп, җан тәслим кылган.* В.Имамов. *Бу вакытта җәрәхәт үлекли башлый, гайморит пәйда булу куркынычы арта.* Саба таңнары

**ҮЛЕКЛЕ** I *с.* Үлек (I) булган. *Акын болай дип җавап биргән: «Үләнле җирдә мал симерер, үлекле җирдә мулла симерер, казакъның караңгы даласын муллалар килеп агартмаса, синең кебек наданнарның башын бет кимерер», – дигән.* Г.Ибраһимов

**ҮЛЕКЛЕ** II *с.* Үлеге (II) булган, үлекләп торган. *Баласының тамагында дифтерия түгел, үлекле ангина булган икән, ул инде терелеп килә.* Д.Каюмова. *Аларда бер яшькә кадәр үлекле йогышлы авыруларга: абсцесслар, пиодермия, фурункулез, омфалит кебек авыруларга карата бирешүчәнлек 8 һәм 11% ка тигез.* Фән һәм тел

**ҮЛЕКЧЕ** *и. сир.* Мәет җирләүче. *Шакыр-шокыр туңып, кызарышып, үлекчеләр кайттылар.* Г.Ибраһимов

**ҮЛЕМ** *и.* 1) Организмда яки аның бер өлешендә матдәләрнең биологик алмашынуы тукталу хәле; организмның һәлак булуы. *Кылганнар – мәңге тукталуны, кибүне, үлемне белмәс дала үләннәре!* В.Имамов. *Үлем исә мәңгелек серләрен эзләүнең тагын бер юлы.* А.Нәҗми

2) Кеше яки хайванның яшәүдән туктау күренеше. *Ничек килсә дә – үлем бер.* Мәкаль. *Шунда үз үлеме белән үләп китә бугай.* А.Хәсәнов

3) *күч.* Хөкем нигезендә үтерү җәзасы. *Демократлар Платонның остазы Сократны да үлемгә хөкем итәләр ---.* А.Тимергалин. *Рөхсәтсез чикне үтүчегә җәзаның да иң көчлесе – үлем җәзасы каралган.* А.Нәҗми

4) *күч.* Бетү, югалу, юкка чыгу күренеше. *Галимнәр дөньядагы 6000 телнең фәкать 600 енә генә үлем куркынычы янамый диләр.* А.Тимергалин

5) *күч.* Бик начар хәл. *Эш-тормышыңны тамак хакына хезмәт итүгә тигезләү иҗат кешесе өчен үлемгә тиң...* А.Гыйләҗев

◊ **Үлем авызы** Һичшиксез үлемгә китерә торган нәрсә; бик куркыныч урын. *Ул бит сугышның эченнән, Газраилнең үлем чалгысы астыннан, үлем авызыннан ычкынып кайткан.* Г.Бәширов. *Ни пычагыма дип син безне үлем авызына алып килдең?* В.Имамов. *Күрәләтә торып ник керттең аны үлем авызына?* Г.Гыйльманов. **Үлем авызыннан тартып алу** Һәлакәт, куркыныч алдында торучыны коткару. *Киресенчә, ул аларның гомерен үлем авызыннан тартып алырга тиеш.* Ш.Маннур. *Сез тагын бер тапкыр карт исәрне үлем авызыннан тартып алдыгыз.* Г.Әпсәләмов. **Үлем аклыгы** Нык курку яки авыру сәбәпле, йөз агару. *Мәрьям исә, баскан урынында катып калып, тыны киселдә, йөзенә үлем аклыгы чыгып, күзләреннән хәят әсәре югалды.* Г.Ибраһимов. *Күп кан югалтуданмы, бүтән сәбәптәнме, егет тәмам хәлсезләнгән, йөзенә үлем аклыгы кунган була.* С.Сабиров. **Үлемгә бару** Бик авыр, куркыныч, үлемгә китерергә мөмкин булган эшкә алыну. *Ә минем өчен директор янына керү – үлемгә бару белән бер.* В.Нуруллин. *Кемнең күрә торып үлемгә барасы килсен?!* А.Хәсәнов. **Үлем исереклеге** Үләр алдыннан аңның чуалуы, төзек фикер йөртә алмау. *Әбинең улы белән килене, моны үлем исереклегенең көйсезлеге генә дип, әбинең ялваруларына игътибар итми икән.* Р.Батулла. *Үләргә яткан көннәрендә төпчеге Мәрьямне чакырып, елый-елый, үлем исереклеген җиңеп, васыятен әйтте ---.* Д.Булатова. **Үлем тырнагы** *к.* **үлем авызы**. *Ләкин өлгерә алмады, Зәйни үлем тырнагына эләккән кебек акырып, ишеккә таба атлады...* Г.Ибраһимов. *Җанымны синең өчен үлем тырнагына бирергә әзер!* З.Мәхмүди. **Үлем тырнагыннан тартып алу** *к.* **үлем авызыннан тартып алу**. *Өметле яралыларны табарга, тизрәк ярдәм күрсәтергә, үлем тырнагыннан тартып алырга тиешләр иде.* Х.Камалов. *Мин аны үлем тырнагыннан тартып алдым.* Н.Фәттах. **Үлем түшәге** Бик көчле, авыр чир; дәваланмаслык авыру. *[Эшче:] Шул кеше кемнеңдер гаебе, җебегәнлеге аркасында үлем түшәгенә егылсын әле.* А.Гыйләҗев. *Ә алар хәтта үлем түшәгендә дә безнең турыда уйлыйлар.* А.Нәҗми. **Үлем түшәгенә (түшәгендә) яту** Бик нык авырудан аяктан калу, авыр хәлдә булу. *Атасы үлем түшәгенә яткач кына кайтып, үткән эшләреннән елый-елый тәүбә итеп, картның бәхиллеген алган.* М.Әмир. *Җитмәсә, әнкәсе үлем түшәгендә ята.* А.Гыйләҗев. **Үлем элмәге** 1) *к.* **үлем авызы**. *Нииндидер бер чүп кенә имза хакына нормаль кеше үзенең улын үлем элмәгенә тыгамыни?* В.Имамов. *Исән калдылар бит, үлем элмәгеннән котылып.* З.Зәйнуллин; 2) Авиациядә элмәкне хәтерләткән югары пилотаж фигурасы. *Истребитель, күз ачып йомганчы өскә чыгып, үлем элмәге ясады ---.* Г.Әпсәләмов. *Аларның берсе, үлем элмәге ясап, бомбардировщикка ут ачты.* Р.Ибраһимов. **Үлем**

**якасы** *к.* **үлем авызы**. *Бөтенләй бетеп җитмәвенә ачу килә килүен, шулай да үлем якасыннан ычкынып, хәзерге хәлгә килүгә дә шатланасың.* Г.Ибраһимов

**ҮЛЕ́-МӘЛЕ** *рәв.* 1) Тирән изелеп, изрәп. *Егет арып, мәлҗерәп бетте, ди. Кайту белән, үле-мәле йокыга китте, ди.* Әкият

2) Бик каты, тәмам хәлдән тайганчы, аяктан егылганчы. *Кайбер олаучылар үзләре генә түгел, атларын да эчертәләр, ә атлар, күзләрен тондырып, иреннәреннән ак күбекләр чыгарып, үле-мәле чаба башлыйлар.* А.Таһиров

**ҮЛЕ́М-БЕТЕМ** *җый. и. к.* **үлем-китем**. *Үлем-бетем бу семья өчен көн саен диярлек ишетелеп торганга, берсен дә ул хәтле тетрәтмәде.* Г.Әпсәләмов

**ҮЛЕМДАР** *и.* Үлем җәзасына хөкем ителгән кеше. *Һәр көн саен кичке сәгать алтыда камерага надзирательләр килеп керә, барлык үлемдарларны чишенергә мәҗбүр итәләр, --- һәр тоткынның кулларына богау киертәләр.* Г.Әпсәләмов. *Бичара үлемдарлар туктаусыз эшлиләр.* А.Расих

**ҮЛЕ́М-ҖИТЕМ** *җый. и. к.* **үлем-китем**. *Күрше-тирәдә дә әллә ни яңалык күзгә ташланмый – үлем-җитем булмаган, Аллага шөкер.* Ә.Баян. *Тормыш ага... Аның үлеме-җитеме бар, дигәндәй, бәла-казасы...* А.Гыйләҗев

**ҮЛЕ́М-КИТЕМ** *җый. и.* Үлү, һәлак булу очраклары. *Үлем-китем очрагы була калса, Петухов мине төрмәдә черетә бит!..* В.Имамов. *Үлем-китем – сугышта гадәти хәл.* Г.Гыйльманов

**ҮЛЕМЛЕ** *с.* 1) Үлә торган; мәңгелек булмаган. *Шулай да ул сорыйсы иткән: – Дөньяда һәммә нәрсә дә үлемле, монысын мин дә беләм, әллә үлемсез бер Аллаһы Тәгалә генәме?* Ф.Яхин

2) Үлемгә дучар булган; үлгән. *Шикле үлемле мәетләр арта.* Татарстан яшьләре

3) Үлем алып килә торган, үлем белән яный торган; үлем-китем күп булган. *Яңгырсыз еллар, кытлык еллар, ач үлемле еллар тагын үзенең бөтен куркынычлары белән авылның йөрәгенә ала башлаган иде.* Г.Ибраһимов. *Менә бит нинди хәтәр, үлемле хәлдән дә исән-имин чыга белгән минем Шамил дус!* Казан утлары

**ҮЛЕМСЕЗ** *с.* 1) Мәңге яши, үлми торган, беркайчан да юкка чыкмый торган. *Томас Морның (1478–1535) хыялый «Утопия»сендә дә халыкның күпчелеге бердәнбер, үлемсез, үлчәүсез, аңлап һәм белеп бетергесез Аллага табына ---.* А.Тимергалин

3) Җиңелү белмәс, һәрвакыт өстен чыга торган. *Үлемсез мафия бу юлы да отышта калды.* Д.Гыйсметдин

4) *күч.* Кешеләр күңелендә мәңге саклана торган, онытылмаслык. *Шушы мәһабәт цехлар, гигант заводлар – сезнең үлемсез эшегезгә мәңгелек һәйкәл ул, әти.* Н.Хәсәнов. *Адәм баласы бары тик җаны, эшләгән эшләре белән генә үлемсез була ала.* А.Хәлим. *Ә, гомумән, шагыйрь үләме? Тәне үлер, шигыре, җыры калыр, Үлемсез бит аның үләне!..* Г.Гыйльманов

**ҮЛЕМСЕЗЛӘШТЕРҮ** *ф.* Үлемсез итү; мәңгеләштерү. *Дөнья һәм дөнья әдәбияты үз исемнәрен бетмәс дан белән үлемсезләштергән күп шагыйрьләрне беләә.* Г.Гомәр

**ҮЛЕМСЕЗЛӘШҮ** *ф.* Үлемсезгә әйләнү; мәңгеләшү

**ҮЛЕМСЕЗЛЕК** *и.* Үлемсез булу. *Әлеге күрәзәче турында ишеткәч, ул, аңардан үзе өчен үлемсезлек алу уе белән, Чань Гунны чакыртып җибәргән.* И.Хуҗин. *Даочылыкта физик үлемсезлеккә ирешүгә әһәмият бирелә.* География

**ҮЛЕМТЕК** *и. этн.* Мәетне җирләгәндә кулланыла торган кирәк-ярак, кәфенлек, садака итеп бирелә торган әйбер, чыгымнарны каплау өчен акча һ.б.ш. *[Тимерхан карт:] Карчыгының үлемтекләр, нафталинлы энҗе калфаклар, көмеш тәңкәләр саклана торган сандыгын ачып, калтыранган куллары белән таушалып беткән өч өчлекне һәм бер тимер берлекне алып бирде.* А.Гыйләҗев. *Яңгырлы озын-озак кичләрдә Суфия еш кына үлемтеккә дигән малларны барларга ярата.* К.Кәримов. *Татар хатыны үлемтек әйберләрен алдан кайгырта.* Ш.Галиев

**ҮЛЕ́М-ҮТЕМ** *җый. и. к.* **үлем-китем**. *Шул ук Новоузенск өязенә кергән Киевка, Олоновка авылларында да ул хәтле халык ачлыкка җәфаланмый, үлем-үтем булмый диярлек.* В.Ильясов

**ҮЛЕП** *рәв.* Гаять, бик нык, чиксез; гадәттән тыш. *Мин бу якны үлеп үз күрәм шул!* А.Хәлим. *Сине бик, Сине бик Үлеп сагындым.* А.Вергазов

◊ **Үлеп тору** Берәр кешене бик ярату, үз итү, аның өчен бөтен уңайлыклар булдыру. *Солтан бабай да, Солтан әби дә, аларның төпчек кызлары Минсара апа да минем өчен үлеп торалар.* В.Нуруллин. *Менә минем апалар да син дип үлеп торалар инде.* А.Гыйләҗев

**ҮЛЕПЛӘР** *рәв. сөйл. к.* **үлеп**. *Мин аны яраттым, мин аңа үлепләр гашыйк булдым, Чокыр кордаш, үлепләр гашыйк булдым.* М.Хәбибуллин. *Фатыйманың үлепләр баласын барып күрәсе килде, йөрәге ярсыды.* З.Кадыйрова

◊ **Үлепләр тору** *к.* **үлеп тору**. *Син әнә гелән кан бирмәсәң дә, углан өчен үлепләр торасың, гәрчә баккан булсаң гына да...* М.Хәбибуллин. *Шәфкатьбикә әбекәем дип үлепләр торыр иде, авыр туфрагы җиңел булсын инде.* С.Поварисов

**ҮЛЕШ** *и.* **1.** 1) Күпләп үлү күренеше, кырылыш. *Әллә кайда, еракта, Комсызлар торган якта – Тагын телиләр, имеш, Булсын дип сугыш, үлеш.* Ш.Маннур. *Җир белән Күк, сугыша-сугыша, Миллиардлап үлеш китәр...* И.Юзеев

**2.** *ы. функ.* 1) Югары, түзеп булмаслык дәрәҗәгә ия хәлне белдерә. *Берзаман шулай Украинада бер ташландык йортның чормасына менеп яшерендек тә юлны күзәтәбез. Төчкерәсе килә бит, каһәр төшкере. Үлеш! --- түзәр әмәл юк.* А.Гыйләҗев. *Үлеш анда! Хәтәр эссе салдым, бал сиптем, иң тәмле чагы...* Р.Батулла

2) Кешедәге, әйбердәге берәр сыйфатның югары дәрәҗәдә булуын белдерә. *[Сания:] Сине бер хатын ике сәгать аулады. Үлеш, шундый фырт!* Н.Гыйматдинова

**ҮЛЕ́Ш-КЫРЫЛЫШ** *җый. и.* Күпләп үлеш, кырылыш; бик каты сугышу күренеше. *Дөньяда бит Сабан туе түгел, Гадел түгел әле орыш. Капчык белән генә сугышмыйлар – Дөнья тулы үлеш-кырылыш.* Р.Ягъфәров. *Киләләр, төрле яктан аталар, миномётлардан сиптерәләр, үлеш-кырылыш.* Безнең мирас

**ҮЛМӘС** *с. к.* **үлемсез**. *Юлдашы Хызыр-Ильяс эчеп карый, мәңге үлмәс әүлияга әверелә дә куя, ди.* Г.Хөсәенов. *Ал кояштай сүнми яктыртучы Татар илле татар кызы мин, Ут-ялкындай очкын таратучы Милләтемнең үлмәс җаны мин!* А.Нәҗми

**ҮЛМӘСГӨЛ** *и. бот.* Оешмачәчәкләләр семьялыгыннан шиңми, сулмый, кипкән хәлдә дә төсен һәм формасын югалтмый торган чәчәкле үлән үсемлек; *русчасы:* **бессмертник**. *Тырнакгөл, мәтрүшкә, бака яфрагы, каен бөресе, үлмәсгөл --- – онкологик чирләрне кисәтүдә кулланыла торган үләннәр.* Мәдәни җомга. *Шулай ук көнгә бер стакан үлмәсгөл үләне төнәтмәсе эчү дә файдалы.* Татарстан яшьләре

**ҮЛМЕШ** *и.* **1.** *сөйл.* Берәүнең үлгән көне, вакыты. *Шуның кебек әгәр кешенең тумышыннан алып үлмешенә кадәр --- бу кешенең дөньяда бар икәнлеген раслый торган төп ике документта --- исем-фамилияләр бозып языла икән, андый документны закон нигезендә кешенең алмаска хакы бар.* Х.Сарьян

**2.** *с. мәгъ.* Үлгән, мәрхүм. *Монда шуны әйтергә кирәк: Алтайдан Днепрга кадәр сузылган киңлекләрдә очрый торган төрки кабер һәйкәлләрендә – балбалларда үлмеш кеше ике куллап кукшин тоткан кыяфәттә сурәтләнә.* Фәнни Татарстан

**ҮЛҮ** *ф.* **1.** 1) Яшәүдән, тереклек итүдән туктау. *Канкояр патша үлгәч, аның урынына өлкән улы Капкорсак-Бушборчакны патша иттеләр, ди.* А.Алиш

2) Һәлак булу; нәрсәдер хакына башны салу. *«Үләргә икән үләргә, тик дошманның үзен дә юк итеп үләргә!» – дип, рация аша утны үз өстебезгә яудыра башлауларын сорадык.* В.Нуруллин. *Син каһарманнарча сугыштың, каһарманнарча үлдең.* Г.Әпсәләмов

3) *күч.* Тәмам югалу, юкка чыгу, бетү. *Үлде рухым. Калмады һич рәхәтем ---.* Г.Тукай. *Кыскасы, халык үзен үзе онытa, үлә...* А.Тимергалин. *Шигырь тумас борын үлде.* В.Нуриев

4) *күч.* Тыну; эшли, хәрәкәтләнә алмас булу. *Мең ярым скважина тынды. Су кудыру насослары үлде.* А.Гыйләҗев

4) *күч.* Кемне яки нәрсәнедер нык ярату, аңа табыну, аның өчен җан ату, бик нык мавыгу. «*Соната*»*лар белән кибет тулган, ә заманында артист халкы аның өчен үлә иде!..* А.Гыйләҗев

5) *күч.* Берәр эш-хәрәкәт, хис һ.б.ш.га артык бирелү, гел шуның белән мәшгуль булу. *Үләсең шикләнеп! Үләсең инде эшләп!*

**2.** *ы. мәгъ.* Шатлану, гаҗәпләнү, зарлану һ.б.ш. хисләрне белдергәндә әйтелә. *Үләм, чукынчык, Галиев дип торам!* М.Мәһдиев. *Уф, үләм, тамагым кипте, аннары ашыйсы да бик килә.* В.Нуруллин. *Җәмилне күрсәң, ак күлмәк өстеннән кара галстугын тагып алган, кыяфәт җитди, билләһи, үләм инде, үләм.* Н.Хәсәнов

◊ **Үләм дисәң дә** Ничек кенә тырышсаң да, берничек тә. *Әтиемнең бит бик хәтәр ягы да бар: шулай дәшми генә йөреп, берәр төрле карарга килсә, аны инде үләм дисәң дә үзгәртеп булмаячак.* Ә.Еники. *Монда, үләм дисәң дә, бер утыргыч тапмассың.* Р.Габделхакова. **Үләр чиктә** Ахыр, иң соңгы чиктә. *Үләр чиктә дә дөреслекне белмәсен.* Сөембикә. **Үлгәндә дә** Беркайчан да. **Үлгәндә дә авызыңа су салмас** Гаять дәрәҗәдә яман, явыз кеше турында. **Үлгән йөрәкле** Хиссез, тойгысыз, битараф кеше. *Шунда ук ире дә утыра: ваемсыз, катып калган, үлгән йөрәкле бер бәндә.* Р.Мостафин. **Үлгәннән калу** Үлә язу, чак кына үлмәү. *Үлгәннән калып, ярты ел урын өстендә яткан Мөнирҗаннан да кабат кеше ясадың бит!* Н.Әхмәдиев. *Шундый каты итеп сукты, Гапсаттар үлгәннән калды.* Ф.Яхин. **Үлдем дә киттем** Көтелмәгән сүздән, гамәлдән нык гаҗәпләнү, шаккату, аптырап калу. *Үлдем дә киттем шушы сүзләрдән.* З.Мәхмүди. **Үлеп терелү** Өмет өзгәннән соң өметләнү, көчле рухи тетрәнүләр кичерү. *Әниебез үзе дә ул көннәрне үлеп терелгәндер.* Безнең гәҗит. **Үлсәм үләм** «Максатка ирешү өчен, бар көчемне куярга әзер» мәгънәсендә. *«Үлсәм үләм, ләкин сезнең ышанычны акламый калмаячакмын!» – дип әйтергә телгән идем.* В.Нуруллин. *Үлсәм үләм, әмма сине урламыйча, моннан китәсем юк.* В.Имамов

**Үлә бару** Рәттән үлү, булган бере үлү. *Балалары туа барды, үлә барды.* З.Зәйнуллин. --- *бүгенге көндә Җир шарында һәр сәгать саен йөз илле тере организм юкка чыга, үлә бара.* А.Хәсәнов

**Үлә башлау** Үлү билгеләре күренү. *Кеше үлем алдында булган, үлә башлаган, ә сез бәладән тартып аласы урынына, гайбәт чәйнәтеп, аңа кабер казыгансыз.* Г.Кутуй. *Кояш нурларыннан мәхрүм калган Җирдә тереклек туңып, шиңеп, сулып үлә башлаган.* Г.Гыйльманов

**Үлеп бару** Акрынлап үлү; әле үлә башлау. *Горур лачын кебек, дошманнары белән көрәшеп үлеп бара ул.* Г.Әпсәләмов. – --- *ике ел инде корылыктан игеннәребез корыды, халкыбыз ачка үлеп бара, малларыбызны да ашап бетердек, сездән игана сорарга килдек! – диделәр.* Г.Гобәйдуллин. *Бу юлы елмайган килеш үлеп барган Сайдәне Түләкнең көчле куллары өскә – якты дөньяга алып чыкмадылар ---.* Г.Гыйльманов

**Үлеп бетү** Барысы да үлү; тәмам үлү, җан бирү. *Мәймүнә пәйгамбәрнең башка хатыннары үлеп беткәнче яшәгән дип сөйлиләр.* А.Тимергалин

**Үлеп җиту** Тәмам үлү. *Сабый бала, туңса да, үлеп җитмәгән иде әле.* Г.Ибраһимов

**Үлеп киту** Көтмәгәндә, кинәт үлү. *Әгәр дә мин үлеп китсәм, Ирочканы эзләп тап.* Г.Кутуй. *Шундый зур империя төзе дә үлеп кит, имеш!* А.Хәсәнов

**Үлеп кую** *к.* **үлеп киту**. *Чыңгызхан көтмәгәндә генә яуда үлеп куя.* А.Хәсәнов

**Үлеп тору** Даими үлү, бер-бер артлы үлү. *Зират кырында яшисез, яшьләр үлеп тора, килгән чаклар булгалар, кагылырмын!* А.Гыйләҗев. *Әгәр гаиләдә бер-бер артлы балалар үлеп торса, яңа туган кызга да, малайга да Калсын, Үлмәс, Үлмәскол, Яшәр, Торсынбай, Торсынай һ.б.ш. исемнәр кушалар.* Г.Шәйхиева

**Үлеп яту** Әле, хәзер үлем кичерү. *Янәшә генә бер сугышчы үлеп ята иде.* Г.Әпсәләмов. *Тиз генә аңламассың да шул: ул үлеп ята, ә аннан: «Ник елыйсың?» – дип сорыйлар.* Г.Гыйльманов

**ҮЛЧӘВЕЧ** *и. к.* **үлчәгеч**. *Гомер буе авырлыкны үлчәп Эштән чыккан Иске үлчәвеч.* Р.Ягъфәров

**ҮЛЧӘГЕЧ** *и.* **1.** 1) Берәр нәрсәнең авырлыгын я озынлыгын үлчи торган әсбап яки махсус җайланма; үлчәү. *Сәлимнәр янына ике-өч адым килеп җитәр-җитмәс, ул туктады да, итек кунычыннан җыелмалы үлчәгеч чыгарып, бер бүрәнәнең пычкы белән ярылмыйча калдырылган төп башын үлчәп карады.* М.Галәү. *Без һәр килгән йөкне сиртмәле үлчәгеч белән үлчибез дә, әрҗәгә күпме сыйганын белгәч, чама белән шул санны язып куябыз.* Ә.Баян

2) *күч.* Эшне, тирә-юньне һ.б.ш.ны бәяли торган нәрсә. *Чын мәхәббәт – барлык нәрсәгә үлчәгеч.* М.Хуҗин. *Тарихны тыңлыйсың, вакыт дигән үлчәгечнең дәвер эзләрен капшыйсың – сокланууң арта.* М.Рәфыйков

**2.** *с. мәгъ.* Нәрсәне дә булса үлчи торган. *Шунда ук үлчәгеч резервуарлар, трап, арматура һәм культбудкалар.* М.Хәсәнов. *Иң авыры шунда: тушәлгән йонның ни калынлыгын, ни тыгызлыгын-тигезлеген үлчәгеч нәрсәләр юк, барысын да бармакларың белән капшап чамаларга туры килә.* Р.Мирхәйдәров

**ҮЛЧӘМ** *и.* 1) Үлчәү берәмлеге. *Ә авырлык үлчәме гөрәнкә дип әйтелә ---.* Ф.Галимуллин. *Аякның аерым өлешләре атамалары да озынлык үлчәмен белдерә ---.* Фән һәм тел

2) Берәр нәрсәнең зурлыгы, күләме; размер. *Мөнә аның көпшәсенең үлчәме!* З.Бигиев. *Яңа шлемнар үлчәмнәре белән бик кечкенә һәм авырлыклары да җиңел иде.* В.Исламетдин

3) Мистик, икенче дөнья урнашкан дип күзалланган яссылык һәм шул

рәвешле урнашкан дөнья. *Ул бүтән дөньяда, бүтән үлчәмдә яши башлады.* Г.Гыйльманов

4) *шигъ.* Шигырьдә ритмның нигезен тәшкил иткән, закончалыклы рәвештә кабатлана торган элементларның (басымлы һәм басымсыз, озын һәм кыска иҗекләр) комбинациясе. *Шигырь азакка кадәр шулай ирекле үлчәмдә бара.* М.Шабаев. *Мөнтәкыйд гарузның дүрт буынлы рәмәл үлчәме белән язылган.* Х.Миңнегулов

5) *мат.* Чагыштырылган ике зурлыкның үзара нисбәте. *20 литрны бишкә тапкырлагач хасил булган саллы базис майлылыгына, ягъни 3,4 кә бүләбез дә хисап үлчәмен чыгарабыз.* Ватаным Татарстан

6) *күч.* Нинди дә булса әйберне, күренешне бәяләү өчен нигез булган нәрсә; бәяләү критерие; үрнәк, эталон. *Алиһә, гүзәллек үлчәме буларак, аның аңында кабына да сүнә.* Р.Батулла. *Ринатның бөтен байлыгы куен кесәсендәге блокнотка язылган җырлар булса, бернечә авылда кибет тоткан Азаматның үз үлчәме иде.* А.Әхмәтгалиева

**ҮЛЧӘМЛӘ́Ү** *ф.* Нинди дә булса гомум кабул ителгән үлчәм белән яисә аерым бер очрак өчен кулланылган үлчәм белән үлчәү. *Кул яссуы белән үлчәмләү*

**ҮЛЧӘМЛЕ** *с.* 1) Билгеле бер үлчәмдәге, үлчәме алынган. *Арада 11 гә 11, 12 гә 12 үлчәмле вәзен төрләре дә бар.* Х.Миңнегулов. *Шундый ук, тик башка үлчәмле бер ишек эшләргә кирәк.* Д.Булатова

2) Үлчәп, үлчәм буенча сатыла торган. *Үлчәмле тәм-том*

3) *күч.* Үлчәп, уйлап эшләгән, эштә һәм сүздә чама белгән. *Яңа заман килсә дә, Сабир Кәшфиевич кебек гамәлдә һәм сүздә үлчәмле затларны үзгәртергә тиз генә мөмкинме?* Ф.Яхин. *Аның кыланышлары үлчәмле, илһамлы, йөзе нурлы, түмәр аягы да үзе кебек.* Казан утлары

**ҮЛЧӘНЕШ** *и.* 1) *физ.* Үлчәү нәтиҗәсе. *Үлчәнеш мәгълүматлары зур төгәллек белән эшкәртелә.* Фән һәм тел. *Биредәге «Ромашкинский» мәйданында эш күләме 162 квадрат километрны тәшкил итә икән, физик үлчәнеш буенча ул 16 мең 700 физик нокта дигән сүз.* Бөгелмә авазы

2) *мат.* Үлчәнә торган зурлык (озынлык, мәйдан, үлчәм). *Картонның баштагы үлчәнешләрен табыгыз.* Алгебра

3) *физ.* Бирелгән зурлыкның берәр системада нигез итеп алынган зурлыклардан бәйлелеген күрсәтә торган аңлатма; *русчасы:* **размерность**

4) *к.* **үлчәм** (*3 мәгъ.*). *Әйтерсең ул башка үлчәнештә яши иде.* Акчарлак

**ҮЛЧӘНЕШЛЕ** *с.* 1) Үлчәнә торган; үлчәп була торган. *Икенчесендә шул ук җыр азәрбайҗан гармунчысы тарафыннан төгәл үлчәнешле лезгинка рәвешендә эшкәртелгән.* К.Гыйззәтов

2) Матди, өчүлчәнешле дөньяга караган. *Суфиларга «үлчәнешле һәм үлчәнешсез дөньялар» төшенчәсе мәгълүм булган.* А.Тимергалин

**ҮЛЧӘНЕШСЕЗ** *с.* 1) *мат.* Үлчәнешләре булмаган, үзләрен уртак үлчәм белән үлчәп булмый торган (чагыштырыла торган саннар тур.). *Квадратның диагонале һәм аның яклары кебек кисемтәләрне үлчәнешсез кисемтәләр дип атыйлар.* Алгебра. *Моның өчен кешеләргә һәм гомумән Җир тереклегенә вакытлыча наноформага күчеп, үлчәнешсез нуль ноктага әйләнеп торырга мөмкин булыр иде.* А.Тимергалин

2) Рухи. *Суфиларга «үлчәнешле һәм үлчәнешсез дөньялар» төшенчәсе мәгълүм булган.* А.Тимергалин

**ҮЛЧӘНЕШСЕЗЛЕК** *и.* Үлчәнешсез булу

**ҮЛЧӘНҮ** *ф.* 1) *кайт. юн. к.* **үлчәү**. *Үлчәнгән идем, авырлыгым арта төшкән.* А.Гыйләҗев

2) *төш. юн. к.* **үлчәү**. *Отчёт собраниесе алдыннан гына барысы да үлчәнеп, исәпкә алынган иде бит ул.* В.Нуруллин. *Йөкләр үлчәнде инде*

3) Берәр нинди үлчәү чарасы белән билгеләнү. *Минем вакыт, кайберәүләрнеке кебек, алай секундлап үлчәнми.* Г.Әпсәләмов

**ҮЛЧӘ́Ү** I *ф.* 1) Махсус корал, җайланмалар ярдәмендә нәрсәнең яки кемнең дә булса озынлыгын, массасын, микъдарын билгеләү. *Ялан үлчәмәгән, сарыклары санамаган, көтүчесе мөгезле (күк, ай, йолдызлар).* Табышмак. *Сырхауханәдә мине җентекләп тикшерәләр, тук-тук китереп күкрәккә, аркага бөккән бармаклары белән суккалыйлар, тыңлыйлар, басымны үлчиләр, телне карыйлар.* З.Зәйнуллин

2) Нәрсәгә дә булса аның зурлыгы, микъдары, күләме һ.б. белән чагыштыру әйбере итеп карау. *Бәхет бит ул – сагыну, акыллым... Мин үземә үлчәп әйтәм моны.* К.Булатова. *Аның туган халкына, авылдашларына күрсәткән игелеген бүгенге тормышның гадәттәге бизмәне белән үлчәп, күнегелгән бәһаләр белән бәяләп тә булмый торгандыр.* Г.Шәйхи

3) *күч.* Күп йөрү, йөренү. *Мондый таза гәүдәсе белән бер дә юктан гына урам буен үлчәп йөрмидер.* М.Кәбиров

4) *күч.* Берәр нәрсәдән чыгып фикер йөртү, нәрсәне дә булса бәяләү; чамалау. *Әле без, инсаннар була торып та, кешене һәм гыйлемен мыегы берлә киеменнән үлчимез.* Г.Тукай. *Һәммә нәрсәгә шул ноктадан карый, шуның буенча үлчи...* Г.Ибраһимов

6) *күч.* Уйлау. *Ах, явыз, саксыз сүз! Кем башлап атты соң? Кем үлчи белмәде сүзләрен?* К.Булатова. – *Үлчәп сөйлә, – диде Рәүф, Өлфәткә күзенең агы белән карап.* А.Тимергалин

7) *күч.* Чагыштыру. *Ни генә язсам да, хәзер бериш иптәшләрем шул пьеса белән чагыштырып карыйлар, шуның нәтиҗәсе белән үлчиләр.* А.Гыйләҗев. *Дөньялар бозылды шул, туган: иман какшады, бердәмлек бетте, бөтен нәрсәне бары тик акча белән генә үлчиләр хәзер.* И.Диндаров

8) *күч.* Сынау, карау, күздән кичерү. *Ул еш кына, дәшми-нитми, кызга озак-озак җентекләп карап тора, нидер үлчи, акылы белән хисен көрәштереп карый иде.* А.Гыйләҗев. *Шулар ук аны энә күзеннән кичереп, күзәтеп-үлчәп утыра.* В.Имамов

**Үлчәп алу** Тиз арада үлчәү. *Мунчадан соң кан басымыгызны үлчәп алыйм.* А.Гыйләҗев. *Надзиратель карандашларны санап, кисеп алып кыскартмаганнармы дип тикшереп, бер-берсенә куеп үлчәп алды да форточканы шап иттереп япты.* И.Салахов

**Үлчәп бетерү** Бөтенесен дә үлчәү; тулысынча үлчәү. *Аны [күз яшен] үлчәп тә бетерерлек хәл юк.* Г.Исхакый. *Бәхетнең гомере кыска, әмма аны кеше гомере белән генә үлчәп бетереп булмыйдыр.* Г.Гыйльманов

**Үлчәп бару** Даими үлчәү; рәттән барысын да үлчәү. *Әмма һәр адымын Людмила Борисовна үлчәп барачагын һәм үзе теләгәнчә аңлатып, боргалап торачагын белмәде.* Ф.Яхин. *Кайсы җиңгән дә кайсы җиңелгән дип өздереп әйтә алмыйбыз, чөнки дөньяда аларны үлчәп барырлык үлчәүләр юк.* Н.Гыйматдинова

**Үлчәп җиткерү** Тиешле дәрәҗәдә, кирәк кадәрле үлчәү. *Ул үзенең фикер сөрешендә һәм эчке мизанында ниндидер җитешсезлек бар икәнен, бөтенесен дә күреп, аңлап һәм үлчәп җиткерә алмаганын аермачык тойды.* А.Тимергалин

**Үлчәп кую** Алдан үлчәү. *Гомумән дә, тормышта Хәмит кебек булырга кирәк ул: һәммә нәрсәне алдан үлчәп куярга, үз кирәгеңне белеп һәм күздә тотып хәрәкәт итәргә!* Ф.Яхин. --- *кайда авыррак һәм кайда җиңелрәк икәнен анда кем ничек итеп алдан үлчәп куя алсын...* Р.Могыйнов

**Үлчәп тору** Даими үлчәү; әле хәзер үлчәү. *– Андый чакта, Фазылҗан, үлчәп торып булмый инде, – диде профессор уйчан гына.* Г.Әпсәләмов. *Тормышта моны уйлап, үлчәп торып буламыни?!* А.Гыйләҗев

**Үлчәп чыгу** Барысын да, тулысынча үлчәү. *Назимов Зубановны күзе белән баштанаяк үлчәп чыкты*. Г.Әпсәләмов. *Таймас Апанаевлар йортының урынын адымлап үлчәп чыкты*. А.Тимергалин

**Үлчи бару** Һәммәсен тоташтан үлчәү. *Без савабыз, тегеләр һәр сыерның сөтен аерып үлчи бара.* К.Тимбикова. *Көймәләр бермләп яр буена чыга торды, хөкемдарлар тотылган балыкны бизмәнгә салып үлчи барды.* Безнең гәҗит

**Үлчи башлау** Үлчәргә тотыну. *Кайда бер җүнле ат күрсә, хәзер шуның тешен карый, тоякларын карый, буенфәләнен үлчи башлый.* Г.Ибраһимов. *Бераз хәл алып яңадан җир үлчи башлый*. А.Гадел

**Үлчи тору** Әлегә үлчәү; һәммәсен үлчәү. *Ә әсәрләрне замана һәм фән бары тик бер генә бизмәнгә салып үлчи торыр, ул тарихи дөреслек һәм әдәбилек тәлинкәләреннән гыйбарәт, аның үлчәм бермлекләре гаделлек булыр.* Ф.Яхин

**ҮЛЧӘ́Ү** II *и.* 1) *сөйл.* Авырлыкны, зурлыкны үлчи торган җайланма. *Өстәлдәге бәләкәй көмеш үлчәүләрдә, колбаларда тәрәзәдән төшкән кояш нурлары чагылып уйный ---*. Г.Әпсәләмов. *Харис Вагыйзович карап-карап торды да үлчәү колгасына тәрәп бастырды мине!* А.Гыйләҗев

2) Массаны, озынлыкны, ераклыкны һ.б.ш. ны билгеләү эше. *Юк, ул заманнарда әле метрлы үлчәү таралмаган бугай, я адым, я сажиндыр.* А.Тимергалин. *Алга таба күкертле водород туплану ихтималы булган урыннарда, иңкүлекләрдә, Красноармейка районында үлчәүләр ясалды.* Әлмәт таңнары

3) Махсус әсбаплар ярдәмендә кирәк кадәрле озынлыкны билгеләп сызу эше. *Тик математик үлчәүләрне генә сирәк эшлим.* В.Исламетдин

4) Кием үлчәме. *Абыең белән без бер үлчәүне кия идек.* А.Гыйләҗев

5) Авырлык. *Канатлар барысы да бертигез үлчәүдә булырга тиеш.* Г.Әпсәләмов

6) Зурлык. *Татар (гарәп) хәрефләренең киңлеге төрле үлчәүдә булганлыктан, тегe яки бу клавишка басканнан соң, тиешле хәрефнең киңлегенә карап, машинканың сикертмә киңлеген дә төрлечә ясавына ирешү өчен, комбинат хезмәткәре Әскәр Шәех-Алигә машинка конструкциясенә үзгәрешләр кертергә туры килә.* А.Тимергалин

7) *к.* **үлчәм** (*4 мәгъ.*). *Строфаларны төрләндерү, үлчәүләрне, ритмиканы баетырга тырышу – Н. Арсланов иҗатының табигый өлеше.* Ә.Баян. *Бәетнең үлчәве дә шул көйгә туры килә.* Г.Рәхим

8) Кыз һәм Чаян йолдызлыклары арасындагы якты йолдызлык. *Үлчәү йолдызлыгы күзгә ташлана торган йолдызлыклардан түгел, һәм халык аны аерып атап йөртмәгән дип уйларга кирәк.* А.Тимергалин. *Әсхәт Үгез елында, Үлчәү йолдызлыгында туган.* Г.Шәйхи

9) Елның шушы йолдызлык күктә күренгән вакыты; зодиак йолдызлыгының 24 сентябрьдән 23 октябрьгә кадәрге вакыты

10) Шул йолдызлыкта туган кеше. *Гаиләле үлчәүләрнең тормышында да яңалыклар көтелә.* Әгерҗе хәбәрләре. *Үлчәүләр өчен апрель ае – иҗади ачышларга бай ай.* Йолдыз

11) *күч.* Бәяләү, бәяләү критерие. *Кабилә, партия, картлык, яшьлек кебек, электән төзелгән үлчәү буенча, боларны һәркемнең дәрәҗәсенә карап өләштеләр.* Г.Ибраһимов. *Хәер, Фәтхулла хәзрәтнең белем даирәсен үлчәргә аның вакыты да тар булды, ә ул белемнәр гадәти үлчәүгә сыймый иде инде.* А.Тимергалин

12) *күч.* Чама. *Котылып чыккач, сөенечемнең үлчәве булмады.* А.Гыйләҗев

◊ **Үлчәве җитмәгән** *к.* **үлчәве таман**. **Үлчәве таман** Бераз акылы җитми торган. **Үлчәве тулмаган** *к.* **үлчәве таман**. **Үлчәүгә салу** 1) Һәр ягын уйлап, чагыштырып карау, чамалау. *Үткәнен һәм киләчәген үлчәүгә салып карады.* И.Нәбиуллина; 2) Берәр мөһим нәрсәне нииндидер максат өчен куркыныч астына кую. *Тормышын да, семьясының бәхетен дә үлчәүгә сала.* Г.Әпсәләмов. **Үлчәүгә сыймау** Чамасыз, әйтеп бетергесез булу. *Ачлыкка түзүе бик авыр, ә җан сызлавы аннан да хәтәррәк, үлчәүгә сыймас.* Ф.Абдуллин. *Үлчәүгә сыймас бу кайгыны да тизрәк үзе белән гүргә алып китәсе килә, күрәсең.* Әгерҗе хәбәрләре

**ҮЛЧӘҮЛЕ** *с.* 1) Үзендә үлчәү II (*1 мәгъ.*) булган, үлчәү белән җиһазландырылган. *Бар иде үлчәүле андый урын.* К.Җәмит. *Бу хакта --- автомобиль юлларында үлчәүле контроль үсеше стратегиясендә әйтелә ---*. Бөгелмә авазы

2) Үлчәнгән, үлчәнеп куелган; үлчәнә торган. *Тоз күп икән монда, үлчәүле тоз...* Н.Акмал. *Монда шулай ук балык, икмәк, үлчәүле товарлар да алырга мөмкин.* Кызыл таң

3) Үлчи торган, үлчәү өчен булган; үлчәү сызыклары булган. *Богатырёв, үлчәүле савыт белән алып килеп, картерга май салды.* Ф.Хөсни

4) Берәр үлчәмдәге. *Котбетдин түзми: – Синең үлчәүле кием табуга караганда, кечкенә үлчәүле хатын табуым ансатрак! – дип ычкындыра.* Ш.Галиев

5) *күч.* Саны, күләме чикле, чамалы; санаулы, аз. *Үлчәүле керемнәрнең нәтиҗәләре дә бик үлчәүле була.* Г.Баруди. *Сыныклап-сыныклап таратсаң да, үлчәүле ипи бит ул.* Х.Хәйруллин. *Үлчәүле нәрсә бик тиз бетте.* Х.Камалов

6) *күч.* Салмак, тигез. *Укытучы салмак, үлчәүле адымнар белән класс буенча йөри.* А.Әхмәт

7) *күч.* Уйланган, исәпләнгән. *Тылсымлы һәм гап-гади, үлчәүле һәм үлчәүсез, вакытлыча сүзләр һәм мәңгелек сүзләр...* Л.Шагыйрьҗан // Уйлап эш итә торган; чама хисен белгән. *Ә мөдир кешегә үлчәүле булырга кирәк.* Ф.Яхин

**ҮЛЧӘҮЛЕЛЕК** *и.* Чамалылык

**ҮЛЧӘҮСЕЗ** *с.* **1.** 1) Үлчи торган җиһазы булмаган; үлчәү куелмаган

2) Үлчәнми торган, үлчәп булмастай. *Томас Морның (1478–1535) хыялый «Утопия»сендә дә халыкның күпчелеге бердәнбер, үлемсез, үлчәүсез, аңлап һәм белеп бетергесез Аллага табына ---*. А.Тимергалин

3) *күч.* Бик күп; чамасыз. *Киң җилкәләр, юан беләкләр, яныл торган таза йөз, шулай ук, әкиятләрдәге диюләр шикелле, үлчәүсез көч атасыннан аңар алдан бирелеп куелган бик зур мирас иде.* К.Тинчурин. *Син үлчәүсез мескенлектә бүген, Котылыр юл синең өчен юк.* К.Булатова

4) *күч.* Төптән уйланмаган, чамадан ашкан. *Әгәр бер як, мәдәни кагыйдәләргә буйсынмыйча, тәртәдән чыгып, үлчәүсез сүзләр куллана башласа, бәхәс хакыйкатьне табуга хезмәт итми ---*. А.Тимергалин

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Үлчәмичә, үлчәп тормыйча. *Үлчәүсез кием кисмиләр.* Мәкаль

2) Бик күп итеп. --- *әйдә, бу карт юләрнең күнеле булсын дип, төрле мактау сүзләрен бернинди үлчәүсез яудыра бирәләр.* М.Әмир

3) *күч.* Төптән уйламыйча. *Үлчәүсез сөйләшү*

**ҮЛЧӘҮЧЕ** *и.* Үлчәү җайланмасын эшләтеп, үлчәп һәм үлчәгәнне билгеләп торучы кеше. *Ындыр табагында үлчәүче булып эшли.* А.Хәлим. *Амбар үлчәүчесе идем, хәзер бүлек начальнигы, фәнни дәрәҗәм дә бар!* К.Кәримов

**ҮЛЧӘШҮ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **үлчәү**. *Ике егет буй үлчәшә.* Табышмак. *– Ягез әле үлчәшегез, кайсыгыз зуррак икән? – дип, малайларны янәшә бастырды.* Ш.Рәкыйпов

2) Сынашу. *Дошман улсаң – килче, көчне үлчәшик! Җөрьәт итсәң – ал кылыч, чап муйнымы!* Т.Ченәкәй. *[Асланов:] Әллә йодрыклар үлчәшәсез инде?* Д.Вәлиев

**Үлчәшә башлау** Үлчәшергә тотыну. --- *шул хакта аршыннарыны алып, бизмәннәрене тотып үлчәшә башларга вакыттыр.* Г.Исхакый

**Үлчәшеп алу** Тиз генә үлчәшү. --- *Мөнир күз кырые белән генә үлчәшеп алды.* Ш.Мотыйгуллин

**Үлчәшеп тору** Даими үлчәшү; хәзер үлчәшү. *Алар да атна саен диярлек үлчәшеп торалар иде.* А.Гыйләҗев

**ҮҢӘЧ** *и.* 1) *анат.* Ашкайнату каналының йоткылык белән ашказаны арасында урнашкан мускул көпшәдән гыйбарәт өлеше. *Кайнар чәй үңәчен көйдереп узды, утлы шар булып, эченә кереп утырды.* Р.Вәлиев. *Су тузбашы белән сары корсаклы полозның (агусыз еланнар) тере табышны үңәчкә төртеп кертә торган кечерәк үткен тешләре бар.* Хайваннар дөньясы

2) *күч.* Муенның әлеге орган үткән турысы. *Хәзер ул теге көчекнең үңәченнән алачак.* Р.Камал

◊ **Үңәч киерү** *к.* **бугаз киерү**. *– Сине дә үзенә каратам дип үңәч киерә, – диде аңа Әнис.* Ә.Хәсәнов. **Үңәчкә үңәч килү** *к.* **бугазга бугаз килү**. *Ул туган елны, сыйнфый көрәш бугазга бугаз, үңәчкә үңәч килеп тартышкан елны, кан елгалары яңгыр сулары белән бергә акты.* А.Алиш. **Үңәч өзелгәнче** Бик тырышып, бөтен көчне куеп. *Үңәче өзелгәнче тырышыр, вакытының бер генә мизгелен дә бушка үткәрмәс, әмма әманәткә хыянәт итмәс...* Казан утлары

**ҮҢГӘ** *с. диал.* 1) Башка, үзгә. *Отсаң – сиңа, отмасаң – үңгә уенцыга.* Милли-мәдәни мирасыбыз

2) Үзенчә. *Бар кеше бер көйгә, ул берүзе үңгә.* Әйтем

3) Җетелеген, үз төсен югалткан, уңган. *Үңгә төстәге*

**ҮҢГӘРҮ** *ф. диал.* 1) *к.* **үзгәрү**. *Явым белән җир күгәрер. Акча белән ир үңгәрер.* Мәкаль. *Элекке түгел бит халык – үңгәрде.* Ә.Баян

2) Төсен югалту, уңу. *Үңгәргән күлмәк*

**Үңгәрә башлау** Үңгәрергә тотыну. *Салам түбәле Кәлимәт артыннан бер канаты китек ай карый, күк йөзендәге буяулар үңгәрә башлый.* Г.Ахунов

**Үңгәреп бетү** Тәмам үңгәрү. *Һә-әй дөньялар!.. Үңгәреп бетеп бара инде.* Х.Сарьян

**ҮПКӘ** I *и. анат.* Кеше һәм күпчелек умырткалы хайваннарның күкрәк куышлыгында урнашкан сулыш алу органы. *Трахея һәм бронхлар аша һава үпкәләргә үтә, анда газ алмашы бара.* Биология. *Үпкәсе шешсә, үлде диген сүз инде ул.* А.Гыйләҗев

◊ **Үпкә кабару** Бик нык ачу килү. *Бибисараның, билгеле, мондый җүләр сүзләрдән үпкәсе кабарды, һәм ул, ачуыннан ярсып: – Тиле әтәч, багана башына менеп кычкыр! – диде.* Н.Гыйматдинова. *Мондый хәлләр --- еш кабатланганга, Айдарның Жорага күптән үпкәсе кабарган иде инде.* Мәйдан. **Үпкә бәлеше** Тиз үпкәләүчән кеше. **Үпкә йөзгәнче** Күп итеп (чәй эчү тур.)

**ҮПКӘ** II *и.* Кемгә дә булса карата аның гаделсезлеге яисә кайбер әхлакый кагыйдәләрне сакламавы сәбәпле туган җәберсенү хисе, хәтер калу, рәнҗеш; кинә. *Ә менә Полканның кешеләргә карата шәхсән тирән үпкәсе, үче, хәтта нәфрәте бар.* А.Хәсәнов. *Гаҗәп, малайның күңелендә көнчелек тә, ачу да, үпкә дә уянмады.* А.Әхмәтгалиева

◊ **Үпкә асрау** *к.* **үпкә саклау**. --- *йөрәгенең иң яшерен бер җирендә кемгәдер үпкә асрый иде.* К.Тинчурин. **Үпкә саклау** Берәр кешегә нинди дә булса сәбәп белән рәнҗеп, үпкәләп тору. *Кешенең язмышы кыл өстендә торган чагында, үпкә саклап тору егет кеше эше түгел бит инде!* В.Нуруллин. *Сез, зинһар, миңа карата үпкә сакламагыз инде.* В.Имамов. **Үпкә тоту** *к.* **үпкә саклау**. *Агач саен кәккүк кычкырганда, Бик ямансу була урманда. Кәккүгемә һич тә үпкә тотмыйм, Калган гомерем кыска булганга.* И.Юзеев. *Мин аңа мыскал да үпкә тотмыйм.* А.Хәсәнов

**ҮПКӘ АВЫРУЫ** *и. мед.* Кох таякчыклары китереп чыгара торган йогышлы авыру; туберкулёз. *[Тукайның] Күптәннән килгән үпкә авыруы көннәнкөн көчәя.* М.Мәһдиев. *Әмма Казанга бабам үпкә авыруы иялтеп кайтып төшә.* А.Хәсәнов

**ҮПКӘ́-БАВЫР** *җый. и.* 1) Суелган хайванның ашарга яраклы эчке органнары (үпкә, бавыр, йөрәк, эчәкләре). *Алар каршысында үпкә-бавырдан, баш-аяктан арзанлы аш пешә.* Г.Ибраһимов. *Әни, өмәче кызларны сыйларга дип, каз итеннән, үпкә-бавырыннан мул итеп аш белән бәлеш пешергән.* Г.Бәширов

2) Кешенең үпкә һәм бавыры; эчке органнары. *Аның тамагы, бөтен үпкәбавырлары көйде.* Г.Әпсәләмов

◊ **Үпкә-бавырга таш булып утыру** Бик авыр тәэсир итү; эчне пошырып, борчып тору. *Шәүкәтнең, Ташкент, Ташкент, диюләре минем үпкә-бавырга таш булып утыра инде.* Д.Каюмова. **Үпкә-бавыры өзелеп киткәндәй булу** Чиктән тыш авыр хисләр кичерү, зур борчулар, кайгы-хәсрәт күтәрү. *Үпкәбавырлары өзелеп киткәндәй булды Миңнулланың.* В.Нуруллин

**ҮПКӘ-ЗАР** *җый. и.* Үпкәләр, зарланулар. *Үпкә-зарлары, рәнҗүләре яңгырап ишетелде.* В.Имамов

◊ **Үпкә-зар тоту** *к.* **үпкә тоту**. *Берберебезгә үпкә-зар тотышмый гына, егетләрчә аерылышыйк.* А.Хәсәнов

**ҮПКӘ́ КАБАРУ** *и. мед.* Үпкә ялкынсыну, пневмония. *LifeNEWS басмасы 600 кешенең үпкәсе кабаруы һәм ике кешенең вафат булуы турында яза.* Безнең гәҗит

**ҮПКӘЛӘТҮ** *ф.* Хәтер калдыру, хаксызга начар сүзләр әйтеп рәнҗетү. *Мөкатдәс абый, ә менә мине үпкәләтәсең килмәсә... йөз тәңкә биреп тор әле.* А.Гадел. *Берәр ярамаган, тузга язмаган нәрсә әйтеп үпкәләттемме?* А.Фәләх

**Үпкәләтә тору** Һаман үпкәләтү

**Үпкәләтеп бетерү** Бик нык үпкәләтү; барысын да үпкәләтү. *– Болай әнә дусларыңны үпкәләтеп бетердең, – дип, ялкынга давыл өсти тәмам борчылган хатын...* Р.Харис

**Үпкәләтеп кую** Уйламаганданитмәгәндә үпкәләтү. *– Кеше әллә ни уйлар, үпкәләтеп куярсың, – дип кисәтү ясый башлаган иде, Гата аңа ике әйтергә урын калдырмады ---.* Н.Әхмә-

диев. *Әйе шул, ханбикәбезне үпкәләтеп куймыйк.* Г.Тарханова

**Үпкәләтеп ташлау** Уйламыйча, кызулык белән бик нык үпкәләтү. *Ләкин Макаевның соңгы сүзләре Зөлкарнәевне бик нык үпкәләтеп ташлады, һәм Зөлкарнәев, урындыгын читкәрәк этеп, бөтенләй сөйләшмәс булды.* Н.Акмал

**ҮПКӘЛӘ́Ү** *ф.* Үзен хаксызга рәнҗетелгән яисә кимсетелгән дип санап, кемгә дә булса үпкә тоту, кинә саклау. *Кодагый, зинһар, гаеп итә күрмәсен, үземнең зиһенсезлегем белән бик зур оятлы булдым, кодагый, зинһар, үпкәли күрмәсен, дигән.* Г.Камал. *Чөнки шулай итмәгәндә, кияүнең, үпкәләп, икенче атнада килми калуы, халык каршында оятка төшерүе ихтимал иде.* Г.Ибраһимов

**Үпкәләп алу** Бераз гына үпкәләү. *– Әби, миннән ник көләсең? – дип үпкәләп тә алган, ди.* Г.Толымбай. *Башта ул мине тыңламый, авыруына борчылып, игътибарсыз калдыра дип үпкәләп тә алган идем.* И.Салахов

**Үпкәләп бетү** Бик нык үпкәләү. *Мин бит монда үпкәләп беттем.* Г.Ибраһимов

**Үпкәләп йөрү** Озак вакытлар үпкәләү. *Мал бүлү талашыннан бирле кияүләр үпкәләп йөриләр.* Г.Ибраһимов. *Мирвәли аңа баштарак үпкәләп йөрде, бераздан күңеле төште, аннары хатынына булган мәхәббәте бөтенләй дә сүнде, суынды.* Г.Гыйльманов

**Үпкәләп кую** Кинәт үпкәләү. *– Монда кадәр кайткач, үзе дә төшерие әле, – дип, кайнатасына да үпкәләп куйды.* Г.Галиева. *Мөхәммәтнең үпкәләп куюы бар.* З.Хөснияр

**Үпкәләп тору** Әле үпкәләү. *– Кайтканына ике көн булды, безгә һаман сәламе юк, дип үпкәләп торадыр идем, – дип күреште, аманлык сорады.* Г.Ибраһимов

**Үпкәләп утыру** *сөйл. к.* **үпкәләп тору**. *Үзе чакырды да хәзер миңа үпкәләп утыра.* З.Хәким

**Үпкәли башлау** Үпкәләргә тотыну. *Болай да үз күчәреннән ычкынган күңелем тәмам тынгысызланды, тынгысызланып кына калмыйча, үртәлә, үпкәли башлады...* Г.Гыйльманов. *– Бар, йокла, Хәйдәр! – диде үпкәли үк башлаган Сәрия.* З.Мәхмүди

**Үпкәли төшү** Бераз үпкәләү. *– Акъярда болай ярыйсы, – диде бабай, үпкәли төшеп.* Г.Әпсәләмов. *– Син күрәзәчеме әллә? – дип сорады үпкәли төшкән кыз.* И.Хуҗин

**ҮПКӘЛӘШ** *и.* Бер-берсенә үпкәләү хәле. *Талаш, үпкәләш тагы кызды.* Г.Ибраһимов. *Гел үпкәләш тә кычкырыш... Димәк, бу мәхәббәт түгел.* А.Гыймадиев

**ҮПКӘЛӘШҮ** *ф. урт. юн. к.* **үпкәләү**. *Ул бала сизмәгәнне дә яхшы төшенә – үпкәләшү онытылган, чын дуслык сакланган.* Л.Минһаҗева

◊ **Үпкәләштән булмасын** Берәр тәнкыйть, шелтә сүзе, нинди дә булса эш алдыннан каршы якларны килештерү, катлаулы мәсьәләне җайлау максаты белән әйтелә торган сүз. – *Әгәр тыңламыйсың икән, анда инде үпкәләштән булмасын!* Г.Бәширов. *Әгәр сайлыйсыз икән, әйдәгез, алдан ук килешеп куйыйк, соңыннан үпкәләштән булмасын.* В.Нуруллин. *Нәселегез белән карун идегез, үпкәләштән булмасын, әткәң гөрс-мәрс башы белән кибеттә сөрсеп ятты.* А.Гыйләҗев

**ҮПКӘЛЕ** *с.* 1) Үпкәләп йөри торган; үпкә саклаган. *Үпкәләргә ярамый, кем әйтмешли, үлгәч, үпкәле кешенең җаны күчеп китә алмый җәфалана, ди...* Г.Гыйльманов

2) Үпкә белдергән, үпкә сизелеп торган. – *Нигә кичә килмәдең? – диде Шура үпкәле тавыш белән.* Г.Әпсәләмов. *Миргарифан өчен дә Фәтхерахман картта үпкәле һәм төртмә сүз күптән әзер.* В.Имамов. --- *әнигә үпкәле караш ташладым да, беркавым ишегалдында таптанып йөргәннән соң, Барыйларга сугыласы иттем.* З.Хөснияр

**ҮПКӘ́-НӨКТӘ** *җый. и.* Үпкәләр, төрле хәтер калулар. *Һәртөрле үпкә-нөктә психологиясе, һәртөрле дәгъва-претензияләр психологиясе аристократизмга ят* ---. А.Тимергалин

**ҮПКӘ́ ПӘРДӘСЕ** *и. к.* **үпкә ярысы**

**ҮПКӘ́-РӘНҖЕШ** *җый. и.* Үпкә һәм рәнҗешләр. *Олы шом, хафалану кичәге үпкә-рәнҗешләрне оныттырган иде инде...* Ф.Садриев. *Үпкә-рәнҗеш тулы күзләре белән Рәфискә текәлеп карап, бер сүз дәшми тик басып тора иде.* А.Вергазов

**ҮПКӘ́-САПКА** *җый. и. к.* **үпкә-нөктә**. *Кая ул ачулану, кая ул үпкә-сапка!* Г.Бәширов. *Таң белән басым яса – Сиңа шулай Тәңре кушкандыр. Үпкә-сапка белән җанын аша, Елап куркыт, елап ышандыр!* Г.Афзал

**ҮПКӘСЕЗ** *с.* **1.** Озак үпкәләп йөрми торган; үпкәчел булмаган. --- *Дәү әни! Ходай аңа безнең барыбызның сурәтләрен нур аша үткәрә торган риясыз, үпкәсез, эчкерсез күңел һәм газаплы чиста вөҗдан биргән!* А.Хәлим

**2.** *рәв. мәгъ.* Үпкәләмичә, үпкәләмәстән. *Карчык исә һич үпкәсез, әмма боек-сагышлы итеп, тирән генә бер сулап куя.* Ә.Еники. *[Мөхәррәм:] Болай булгач үпкәсез, рәнҗешсез китәсең инде?* Ю.Әминов

**ҮПКӘ ҮЛӘНЕ** *и. бот.* Кыярчалар семьялыгыннан чәчәк ата башлаганда таҗлары ал, атып беткәндә зәңгәр төскә керә торган күпьеллык үсемлек; *русчасы:* **медуница неясная**

**ҮПКӘЧӘН** *с. к.* **үпкәчел**. *Гарифә кодагый түбәнгә кала күрмәсен. Бик үпкәчән, бик гаепчән кеше.* Г.Камал. *Ләкин шук шәкертләр ятрак киемле һәм бик үпкәчән холыклы Зәки шәкертне беренче көннәрдән үк ят күрәләр* ---. Л.Хәмидуллин

**ҮПКӘЧӘНЛЕК** *и. к.* **үпкәчеллек**. *Үпкәчәнлек – иркәлек галәмәте.* Әйтем. *Шушы юл белән кияүнең үпкәчәнлеген бетерергә, сабырлыкка өйрәтергә теләгәннәр.* Х.Мәхмүтов

**ҮПКӘЧЕЛ** *с.* Тиз үпкәли торган. *Үпкәчел кыз бәхетле, үпкәчел егет бәхетсез була, ди.* Әйтем. *Җә, җә андый ук үпкәчел бала булма инде.* З.Мәхмүди

**ҮПКӘЧЕЛЛЕК** *и.* Үпкәчел булу сыйфаты. *Үпкәчеллек бар Анысы миндә.* Р.Миңнуллин. *Әллә артык нечкә күңелле булганга, әллә үпкәчеллеге аркасында, кызларның берсе белән дә якынаеп китә алмады [бу кыз].* М.Маликова

**ҮПКӘ́ ЯРЫСЫ** *и. мед.* Үпкәнең тышкы ягын һәм күкрәк куышлыгының эчке ягын каплап торган яры; *русчасы:* **плевра**. *Операция барышында тагын Юматшаның ике кабыргасы сынганлыгы, үпкә ярысы ертылып, үпкәсенә кан савылуы беленде.* Г.Әпсәләмов. *Баксаң, үпкә кабарганда һәм үпкә ярысы ялкынсынып шешкәндә (плеврит), пешкән шалканны күкрәккә япсаң яисә ашасаң, яхшы дәва була икән.* Ватаным Татарстан

**ҮР** *и.* 1) Сөзәкләнеп менгән, ләкин биек булмаган озын тау бите. *Урман алдындагы үрне менгәч, такта заводының тимер морҗасы күренде.* А.Алиш. --- *Фәйрүзә апа да, башка олаучылар да, үргә җиткәндә йөкләреннән төшеп, артка калдылар.* В.Нуруллин // Ясалма калкулык. *Бу шәһәрләр кырыйларыннан үр белән әйләндереп алган булып, үрнең тышыннан биек койма белән чолганган иде.* Г.Гобәйдуллин

2) Нәрсәнең дә булса югарыгы ягы. *Григорий урам буйлап үргә менеп китте.* А.Хәлим. *Югары очка, үргә каршы элдергән була...* А.Гыйләҗев // Гомумән

өске як. *[Шәрәф] артына әйләнеп карамый, күктән килгән тавышны тыңлагандай, башын үргә күтәрә.* М.Фәйзи

3) *күч.* Берәр эштәге зур уңыш; үсешнең югары ноктасы; иң мөһим, иң төп нәрсә. *Тормыш өчен иң мөһим үрне алгач, Замир тагын да рәхмәтле булып, бирелеп хезмәт итә башлады.* Т.Галиуллин

◊ **Үргә җибәрмәү** Артык озайтмау. *Фәтхулла аның сүзен үргә җибәрмәде, йомшак ата тавышы белән [кире какты].* Ш.Камал // Эшне зурга җибәрмәскә тырышу. **Үргә китү** Эшләр уңайга китү, әйбәтләнү. --- *барыннан да бигрәк коллективта катгый тәртип булдыруы уңай нәтиҗәләрен озак көттермәде – күрсәткечләр үргә китте.* Безнең гәҗит. *Ул килгәч, эш бермә-бер үргә китте, тапшырулар күләме һәм көннәре артты.* Сарман. **Үргә менү** Ныграк үсеш алу, үсештә югарырак баскычка күтәрелү. *Бу елларда үргә менгән саен, Ходам биргән үҗәт көч белән, Түбәнсетүләрне күп татыдым...* Л.Шагыйрьҗан. *Тукай юкса татар үргә менгән, чәчәк аткан чорда яшәгән икән әле ул.* Р.Юныс. **Үрдән төшү** Яулаган уңышларны, отышларны югалту. *Ак син, җырым, Әтил сыман дулкынланып. Тыңла, бала, шул дулкынны уйга талып. Бабай менгән рухи үрдән төшә күрмә. Төшә күрмә, Алыплардан калган халык!* И.Юзеев. --- *без дибез, Ә үзебез кимибез, Һаман үрдән төшәбез, Һаман түрдән төшәбез, Һәм... хәтердән төшәбез.* Л.Мөгътәсимова

**ҮРӘ** *рәв.* 1) Вертикаль рәвештә, перпендикуляр буенча. *Көймә дулкыннарның сыртына менгәндә үрә баса, аннары күз иярмәс тизлек белән аска ыргыла, тагын үрә күтәрелә.* Г.Әпсәләмов. *Җәүдәт кузгалды, Наза да аңа иярде, ачып җибәрсәләр, коридорда кыска тун якасын үрә бастырып куйган, колакчынлы бүреген кашларына төшергән ир басып тора.* А.Гыйләҗев

2) Сынны туры тотып. *Курыкты [немец] үзе күреп, аяксыз да Минем үрә торып басканны.* М.Җәлил

◊ **Үрә(гә) кату** 1) Сынны туры, төз тотып, хәрәкәтсез тору. *– Җир йотсын, без алмадык, вашесокородие! – диде ул, үрә катып һәм честь биреп.* В.Нуруллин. *Тимер капкалар ачыла, караучылар үрә катып честь бирәләр ---.* А.Гыйләҗев; 2) Берни эшләмәү; эшсез йөрү, эшләргә гадәтләнмәү. *Үзләре генә киерелеп, киенеп, үргә катып йөрсеннәр, имеш.* Г.Камал. *Син, Самат, нәрсә үрә катып торасың? Чәй куеп җибәр!* Р.Бәшәр. **Үрә карау** 1) Башны югары күтәреп, берни күрмәгән булып йөрү. *Аңлардайлар аңлар кебек, Күрердәйләр күрер кебек Үрә карап йөргәннәрне, Күзгә салкын пәрдә корып, Янгынны да читләп узып. Кычкырмыйча «әдәп саклап», Үтеп китә алганнарны Төп-төз атлап, намус таптап.* Н.Измайлова; 2) Тырпаеп басып тору (чәч тур.) *Солдат чәче үрә карый, Көн саен майлап тарый.* Ш.Маннур. **Үрә сикерү** 1) Арткы аякларга басып югарыга сикерү. --- *айгыр, яшен тизлеге белән кире чигенеп, авызының тартылуына чыдаша алмыйча, алгы аяклары белән, гүя күккә омтылып, үрә сикерә, дулый башлады.* Г.Ибраһимов; 2) Бик шатлану, шатлыктан нишләргә белмәү. *Роберт аның тәкъдимен ишетү белән үрә сикерде: – Менә яхшы була! Казанны да күрәбез!* М.Кәбиров. **Үрә тору** 1) Торып басу. *Зөләйха моны ишеткәч үрә торды, Хәлне аңлап, зиһенен һәм гаклын җыйды ---.* Кол Гали. --- *котыра башлаган үгезне коткарырга самолётта очып килгән профессор сәхнәгә керү белән, бөтен зал үрә торып кул чабарга керешә.* Т.Гыйззәт; 2) Арт аякларга басу. *Караңгы абзардан көн яктысына чыккан айгыр, арт аякларына басып, үрә торырга, ычкынып, кырларга чабып китәргә ашкына.* Г.Әпсәләмов. *Күктимер кинәт кенә арт аякларына басып үрә торды да дошманына каршы китте.* Р.Камал; 3) Тырпаю (чәч, төк тур.). *Инде һәртөрле зәһәрләр һәм каһәрләрдән эче Туп-тулы булды песинең, Кайраладыр һәр теше. Һәм үрә торды, кабарды бар тәненең һәр төге, Үч алу дәртендә гүя һәр төгенең бөртеге!* Г.Тукай. *Ул чакта Бакыйның чәчләре үрә торды.* Г.Әпсәләмов; 4) Тик тору. *Урам уртасында тилиграм баганасы сымак үрә торып булмый, әйдә, җаным, урап килик әле.* В.Имамов

**ҮРӘН КАЛАГЫ** *и. диал.* Зур кабырчык. *Күз кайтару өчен, кечкенә кәләпүшенә гөбе тимере, тиен койрыгы, үрән калагы тектеләр.* Г.Исхакый

**ҮРӘЧӘ** *и.* Арба яки чананың якягында буйга сузылып, аларның киңлеген арттыра торган иң тышкы агач. *Ә Гөлбану, үрәчәдән башын иеп, көпчәкләрнең былчырак юлга тирән эз сызып тәгәрәвен карап барды.* М.Хәсәнов. *Свердлау урманнарыннан аякларына ырматиз эләктереп кайткан уллары Миңнетдин, арба үрәчәсенә чалкан ятып, каз мае сыланган балтырларын кояш нурында мунча кертә.* А.Хәлим

**ҮРГЕ** I *с.* Биегрәк, югарырак урында булган; өске, югарыгы. *Инде бусы чын иде: өсләре ашъяулыклар белән ябулы гөбеләр, батманнар куелган, шуларны кочаклап ике малай, бер хатын утырган зур ящик арба безнең җирнең үрге башына килеп тә туктады.* Г.Ибраһимов. *Менә шушы урманлы тауны гына менеп төшәсе дә, Чирмешкулны үтеп, авылның үрге очына килеп керәсе.* И.Хуҗин

**ҮРГЕ** II *и.* Шытым, үренте

**ҮРГЕЛЕК** *и.* Үрчетү өчен кулланыла торган ботак; бөре ботак. *Үсемлекләрнең вегетатив орган өлешләреннән: мыекчалардан, үргелекләрдән, тамырчалардан, суганчалардан, бүлбеләрдән һәм чыбыкчалардан үрчетү дә нә шулай бара.* Ботаника

**ҮРГЕМЛЕ** *с. диал. к.* **үрчемле**. *Күмәк эш үргемле була.* Мәкаль

**ҮРГЕН** *и. диал. биол. к.* **үренте**. *Кура җиләге куакларында яңа үргеннәр күренә башлагач, аларның иң көчлеләрен сайлап алалар.* Өегез ямьле булсын

**ҮРГЕЧ** *и. к.* **чәчүргеч**. *Ул битенә иннек-кершән сөртте, чәчләрен майлады һәм чулпылы үргечләр белән ике толымга аерып үрде дә көмеш тәңкәләр белән бизәлгән калфагын баш түбәсенә кадап куйды.* М.Галәү. *Безнең әниләр, әбиләр дә пөхтәләп тарап үргән толымнарын шундый үргечләр белән төйнәп куя иде бит.* Ватаным Татарстан

**ҮРГҮ** *ф. диал.* 1) Үрү, шыту. *Ашлык үргегән*

2) *күч.* Арту; күтәрелү. *Эш бергәләп эшләгәндә генә үрги.* Мәкаль

**Үргеп китү** Тора-бара үргү. *Сүз сүрән генә үргеп китте.* А.Гыйләҗев

**Үргеп тору** Даими, әледән-әле үргү. *Куанычлар сүмәләктәй үргеп торсын.* С.Әхмәтҗанова

**ҮРДӘК** *и.* **1.** *зоол.* 1) Үрдәкчәләр семьялыгыннан яссы томшыклы, кыска муенлы, кыска канатлы, кыска аяклы киек яки йортлаштырылган су кошы. *Тавыклары күп, келәт алдында үрдәкләр, бакылдап, җим теләнеп торалар...* А.Гыйләҗев. *Үрдәк ату сезоны әле ябылмаган.* А.Хәсәнов

2) Шул кошның ите. *Бламаҗилары оемаган, дигәннән исемә төште: бер көннәре мин Чурчи Әхмәтләргә ашка барган идем, үрдәк бөккәннәре бер дә пешмәгән, авызга алгысыз чи иде, бөтенләй лачкылдап тора.* Г.Камал. *Артист авызын тутырып ашарга башлый, үрдәкне ботыннан тотып кимерә...* Г.Исхакый

**2.** *с. мәгъ.* 1) Киң һәм зур (борын тур.). *Олы, таза гәүдәле, уртачадан озынрак буйлы, бөдрә чәчле --- үрдәк борынлы, гелән йөгереп торган соры күзлесе өстенә аклы, кызыллы, караллы тукымадан «Адидас» спорт киемен элгән.* Т.Галиуллин

2) *күч.* Ялган. *Үрдәк хәбәрләр*

◊ **Үрдәк очыру** Ялган хәбәр тарату. *Тегеннән берсе Истанбулда тормышның җиңеллеген, солтан тарафыннан фәлән нәрсә бирелә, фәлән нәрсә бирелә, диеп, үзеннән үрдәк очыра иде.* Г.Исхакый. **Үрдәк теле ашаган** Күп сөйләшә торган

**ҮРДӘКӘЧ** *и. сөйл.* 1) Үрдәк бәпкәсе

2) Инде шактый үскән үрдәк баласы, төсе каралган бәпкә

**ҮРДӘКБОРЫН** I *и. зоол.* Үрдәкборынчалар семьялыгыннан үрдәкнекедәй яссы томшыклы, кондызныкыдай койрыклы, күкәй салып үрчи һәм Австралиядә генә очрый торган имезүче хайван. *Клоакалыларга (беренчел җәнлекләргә) үрдәкборын, ехидна һәм аңа якын проехидна гына керә.* Биология

**ҮРДӘКБОРЫН** II *и.* Яссы ирнәүле келәшчә. *Тимерче кораллары – ике куллап тота торган зур, авыр чүкеч (балда яки дөлдә, русча – молот, кувалда), вак чүкечләр, кыпсуырлар (келәшчәләр), үрдәкборыннар, каргаборыннар, кискечләр, тишкечләр, боргычлар --- шулай ук кул астында гына.* А.Тимергалин

**ҮРДӘКБОРЫ́НЧАЛАР** *и. күпл. зоол.* Берьюллылар отрядыннан хәзерге вакытта сакланып калган бердәнбер төрне – үрдәкборынны һәм бернечә үле төрне берләштергән имезүче хайваннар семьялыгы

**ҮРДӘК-КАЗ** *җый. и.* Үрдәкләр һәм казлар, су кошлары. *Бездә су мәсьәләсе шактый четерекле, ике-өч чишмәдән башка авыл тирәсендә һичнинди елгакүл булмаганга, үрдәк-каз үстереп котая алмадык.* В.Нуруллин. *Челәннәр, торналар, аккошлар, үрдәк-казлар соңрак кузгалалар.* А.Хәсәнов

**ҮРДӘ́КЧӘЛӘР** *и. күпл. зоол.* Казсыманнар отрядыннан аккошларны, казларны, бүрекле үрдәкләрне, елга үрдәкләрен һ.б.ны берләштергән семьялык

**ҮРДЕРҮ** I *ф. йөкл. юн. к.* **үрү** I. *Беренче мәхәббәт, кайда син?! Уйнаткан, көлдергән, Такыялар үрдергән ---.* Ә.Низамова

**ҮРДЕРҮ** II *ф. йөкл. юн. к.* **үрү** II. *Үрдерергә бәрәңге чыгару әле безнең истә дә юк, ә Барый абый инде күптән чыгарган.* Р.Газиз. – *Салат онына арыш үрдерәм, – диде хатын, тавышын горур гөрелдәтеп.* К.Кәримов

**Үрдереп алу** Аз гына үрдерү

**Үрдереп карау** Сынау өчен үрдерү. *Әгәр дә сатып алган орлык тишелерме, тишелмәсме дип шөбһәле булса, төбе тишек чүлмәккә ком салып, юеш комда ул орлыкны үрдереп карарга кирәк.* К.Насыйри

**Үрдереп кую** Алдан үрдерү. *Орлык бәрәңгеләрен әзерләп, үрдереп куйган идек инде.* Шәһри Казан

**ҮРЕЛМӘ** *и.* **1.** 1) Җепләрдән, тукымадан һ.б.ш.дан үреп эшләнгән нәрсә. *Аларга әле яңалары: амигуруми (элмәк яки биш инә белән төрле төстәге кечкенә уенчык бәйләү) һәм кумихимо (--- җептән, баудан, шнурдан үрелмәләр ясау, бизәнү әйберләре үрү) дә өстәлде.* Сабантуй. *--- өстәлдәге җиләкҗимешләр тутырылган кәрзин яисә суган, сарымсак яки кипкән кызыл борычларның декоратив үрелмәләре, бөтнек яки дәфнә яфрагыннан үрелгән такыялар аш бүлмәсенә үзенә күрә бер ямь өсти.* Кәеф ничек?

2) Бер-берсенә үрелгән, бәйләнгән, тоташып, керешеп киткән нәрсә. *--- алар музыкаль ритмны тудыра торган чараларны фәнни анализ эзләп тапкан элемент итеп түгел, бәлки күңелгә тәэсир итә торган матур яңгырашлы аваз үрелмәләре итеп таныганнар, шулай үзләштергәннәр.* Х.Госман. *Җыентыкны укыганнан соң, вакыйгалар үрелмәсенә битараф калу мөмкин түгел!* Безнең гәҗит

3) Бер-берсенә үреп ясалган бизәкләр. *Бер бизәге ватылса, сәгатьләр буе эшләгән үрелмәң утынга әйләнә дә куя.* Р.Газиз

4) Ике төшенчә, күренеш бер-берсенә керешеп хасил иткән бербөтен; ике нәрсәнең синтезы. *Күренекле төркиятчы тел галиме Әдһәм Тенишев, мәсәлән, Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» дастанында өч тел традициясенең үрелмәсен күрә.* Н.Хисамов

3) *махс.* Нерв төеннәре җыелмасы. *Моның өчен без еш кына новокаин блокадасын, ягъни кара кан тамырына яисә корсак куышлыгындагы нервлар үрелмәсенә новокаин кертү алымын кулланабыз.* Ф.Әгъзамов. *Күкрәгенә, кояш үрелмәсе турысына суга.* Кызыл таң

4) *күч.* Бер-берсенә керешү, кушылу. *Тормыш үзе шундый үрелмәләр белән чәбәләнеп беткән.* Х.Госман

**2.** *с. мәгъ.* Үреп эшләнгән. *Кыекча изүле кара сатин күлмәген билдән үрелмә тасма белән буып йөрүе дә, тездән югары балтырлы хром итекләре дә – гомумән барысы да заманында аның оста куллы кешеләр «университетын» үткәнлеген әйтеп тора.* М.Глухов

**ҮРЕЛМӘЛЕ** *с.* 1) Үреп ясалган; бормалап эшләнгән. *Син учымдагы үрелмәле көмеш чылбырга тагылган алтын тәңкәгә озак карап тордың.* Ә.Гаффар

2) Берәр нәрсә тирәсендә уралып, чорналып үскән; уралган. *Аларның асларыннан үрелмәле яфраклар үсеп чыга.* Казан утлары. *Быелгы фестивальнең темасы – «Семирамиданың үрелмәле бакчалары» ---.* Шәһри Чаллы

3) Бормаланып, бер-берсенә керешеп үтә торган. *Сукмаклар, юллар тирәдә Бормалы, үрелмәле. Улкаем белән бергәләп Кырларда йөрим әле.* К.Булатова. *Зөбәергә кайтыр юлым Бормалы, үрелмәле. Урам очларына бассаң, Кырлары күренмәле.* Э.Шәрифуллина

**ҮРЕЛҮ** I *ф.* 1) *төш. юн. к.* **үрү**. *Татар чабатасы тар юкәдән кечкенә башлы итеп үрелгән.* А.Тимергалин. *Иңнәреңә челтәрләп үрелгән ак шәл ябынгансың ---.* А.Мансуров

2) *күч.* Үзара бәйләнү, бер-берсенә кушылып китү. *Аның көенә әйтерсең Хәйдәре көйләгән моңнар да килеп кушылды, шуңа өстәп, тагын бик күп, бик күп Наласа егетләренең җырланмаган җырлары да үрелеп акты...* Г.Әдһәмова. *Фәкать галимлек һәм шагыйрьлек бергә үрелгәндә, пәйгамбәргә вәхи килгәндәгегә охшашлырак халәт кичергәндә генә, Коръән тәрҗемәсе яки тәфсире оригинал югарылыгына азмы-күпме якыная алачак.* А.Тимергалин // Тоташу. *Башымдагы уйлар менә тагын Үткәннәргә килеп үрелде.* Г.Гайнетдинова

**Үреләә бару** Торган саен ныграк үрелү. *Хәдичә бу ике яшь йөрәк арасында мәхәббәт җепләренең торган саен ныграк үреләә баруын күреп-тоеп утырды ---.* Г.Галиева

**Үрелеп бару** Берсе артыннан берсе үрелү; эзлекле рәвештә үрелү. *Бу кырда (басуда, бакчада) миллилек һәм бәйнәлмиләл юнәлешләре тыгыз үрелеп барса гына, уңышка ирешәчәкбез, җимеш алачакбыз.* А.Тимергалин. *Фирдәүси белән Низаминың һәр газәле әнә шул исерткеч гыйшык җепләренә үрелеп бара лабаса!* В.Имамов

**Үрелеп бетү** Бик нык үрелү. *Стеналар буйлап үрелеп беткән төрле*

*трубалар сузылган.* Г.Әпсәләмов. *Субтропик урманнарның үзенчәлеге – лианалар белән үрелеп беткән эвкалипт төрләренең күплеге. Анда шулай ук агачсыман абагалар да үсә.* Материклар һәм океаннар географиясе

**Үрелеп килү** Күптәннән үрелү. *Аның изге теләге белән яшьләрнең матур гаилә коруларын үкенечләр белән үрелеп килгән моңсу бәхет диме ни дисең...* Г.Галиева

**Үрелеп китү** Акрынлап, җае белән үрелү. *Мәҗлес майлагандай көйле генә үрелеп китте шулай.* Р.Мөхәммәдиев. *Дөнья кайгысын кайгырткан шагыйрә иҗатына Милләт кайгысы да табигый рәвештә үрелеп китә төсле.* И.Вәлиулла

**ҮРЕЛҮ** II *ф.* 1) Берәр нәрсәне яки кемне күрү, алу, тоту нияте белән бөтен гәүдә белән тартылу, башны, кулны сузу. *[Еланнарның кайберләре] Көтүләп йөргән сыерларның аягына чорналып, җиленнәренә үреләләр.* А.Хәсәнов. *Гөлфинур, үзен җиңеп, ашамлыкларга үрелгән булды, минераль су эчеп куйды.* А.Вергазов. *Утырып баручылар бар да, үрелеп, баланы карадылар.* А.Нәҗми

2) Берәр якка борылып, тартылып үсү (үсемлекләр тур.). *Иж буенда куе кара урман, Күккә үрелеп үсә чыршылар.* Г.Сафин

3) *к.* **үрләү**. *Мәйданның бер почмагында дегет төсле кара төтен зәңгәр һавага үрелеп, аның кызыл телләрен сузган ялкыннар күренеп тора, ди.* А.Алиш

4) *күч.* Берәр нәрсәгә ия булырга яисә ирешергә тырышу, омтылу. *Сезнең нинди тир белән табылган байлыкларга үрелмәкче...* Г.Каюмов. *Әле Минай хәтле Минай ханны әйләндереп төшерергә үрелә бу* ---. В.Имамов

**Үрелә башлау** Үрелергә тотыну. *Ут алыйм дип ширпыга үрелә башласам, шап минем кулга!* Г.Бәширов. *Рәдиф шкафларындагы шешәгә үрелә башлагач, мин түзеп тора алмадым.* В.Нуруллин

**Үрелә бирү** *к.* **үрелә төшү**. *Ул, сәкедән кузгалып, идән уртасына басты да үрелә биреп урамга, анда шаулаган күсәкле, сәнәкле мужиклар ягына карады.* Г.Ибраһимов. *[Ул] ---, үрелә биреп, әрекмәннәр арасыннан әйрәнле чирекне эләктереп чыгарды.* А.Хәлим

**Үрелә тору** Торган саен, әледән-әле үрелү. *Мактый-мактый, табындагы барлык әйберләргә үрелә торды, алар берәм-берәм абыйның олы авызына кереп югала тордылар.* Ялкын

**Үрелә төшү** Бераз үрелү. *Данәгөл, үрелә төшеп, кулын әтисенең иңбашына салды* ---. А.Хәсәнов. *Рәфис, Рәниянең шулай самими гына бераз кыланып сөйләшүенә кәефе килеп, үрелә төшеп, аның кулыннан тотып алды.* А.Вергазов

**Үрелеп җитү** Кирәк кадәрле үрелү. *Ә үзе, Миңнулла Зәйнәпкә үрелеп җитәм дигәндә генә, ялт күтәрелеп куя.* В.Нуруллин. *Ләкин үрелеп үк җитә алмый, көчсезләнеп сүнеп кала, шунлыктан җирдәге ут күзләре белән күктәге йолдызлар арасында калын караңгылык дәрьясы ята.* З.Мурсиев

**Үрелеп кую** Көтмәгәндә үрелү. *Рәшидә, кирәкми дигәндәй, тәлинкәсенә үрелеп куйды, ләкин бер сүз дә әйтмәде.* Ә.Еники. *Тәнзилә, кулын чак кыймылдатып, ак халатлы врачка үрелеп куйды.* Н.Акмал

**Үрелеп тору** Әле, хәзер үрелү; даими үрелү. *Тәрәзәгә үрелеп торган юкәләр дә, бизәкле кәрнизле йортлар да – барысы да матур иде.* Н.Акмал. *Бер катлы, ике катлы иске таза агач йортларның бакчаларыннан үрелеп торган шомырт һәм сирень чәчәкләре тирәюньгә хуш ис тарата.* З.Мәхмүди

**Үрелеп яту** *сөйл. к.* **үрелеп тору**. *Әхмәт абзый да, бүген үзенең артыграк сөйләшеп ташлавыннан кыенсынып калган сыман, һаман әле чишмә инешенә үрелеп яткан атын ачулана* ---. М.Мәһдиев

**ҮРЕМ** *и.* 1) Үрелгән чәч, толым. *Үремгә кермәгән бер томам маңгай чәче күзенә төшеп интектерә.* С.Зыялы. *Аның озын кара чәчләре, тугыз үремгә үрелеп, аркасына салынып тора.* Н.Фәттах

2) Толымдай үрелгән нәрсә. *Үремгә суганнар тезелгән, үрелгән чәч сыман тора.* Ш.Галиев. *Чәчәк үремнәре шикелле буй-буй сузылган әнә шул асылмалар чишмә агышыдай уйнаклап киләләр дә асылташлар куелган эре челтәр-тәңкәләргә барып тоташалар.* Казан утлары

3) Агачның нечкә, сыек асылынып торган ботаклары. *Каеннарның шәлбер үремнәре Бәс чәчәкләр белән үрелгән.* Ш.Маннур

4) *күч.* Берничә элементның, күренешнең бер-берсенә бәйләнү, керешү күренеше. *Бу эш бер-берсен үстерә, яхшырта торган ике юнәлешнең тыгыз үреме рәвешендә бара* ---. Фән һәм тел

**ҮРЕМЛӘ́Ү** *ф. сөйл.* Үрү (чәч тур.)

**ҮРЕМТӘ** *и.* Бер үрем хасил иткән кисәк. *Фән тарихыбызда XX гасырның беренче чирege татар мәдәниятенә кагылышлы материалларны, гарәп графикасында сакланган көндәлек матбугат язмаларын, архив документларын, истәлекләрне гади һәм үтемле рәвештә бу кадәр колачлы итеп гыйльми эшкәрткән, бер үремтәдә карый һәм бәяли алган башка бер шәхесне аерып күрсәтү дә авыр!* М.Мәһдиев. *Романның иркен һәм сыйдырышлы композициясе үткән белән хәзергене якынлаштырып, бер үремтәдә сурәтләргә мөмкинлек бирә.* Әдәбият

**ҮРЕНТЕ** *и.* 1) Ачык туфракка күчереп утырту өчен махсус җылы түтәлләрдә яки савытларда үстерелгән үсемлек. --- *тамырлы сельдерей уңышын октябрьдә җыярга исәп тотсагыз, аның үрентесен 200 көн, яфраклысын 100 көн алдан утыртырга кирәк.* Кызыл таң

2) Үсемлекнең орлыктан яки тамырыннан шытып чыккан сабакчасы. *Һәр агач та үз төбеннән яшь үрентеләр җибәрә алмый.* Н.Әхмәдиев. *Ул басуга да бодай чәчелгән иде, ләкин үрентеләр монда озынрак, куерак һәм юка, нечкә сабак очларында инде яшел чырай күренә башлаган иде.* Н.Фәттах

3) *күч.* Берәр нәрсәнең әле зәгыйфь, әмма үсеш алырга мөмкин булган башлангычы. *Аңа егетләр белән урам әйләнү, клубта иптәш кызлары илә ләчтит сатып утыру кызыграк тоела, миендә исә дөньяда бер тапкыр гына яшәү фәлсәфәсе, укымаганнар ким-хур яшәми дигән ышаныч тирән үренте җибәрә.* Т.Галиуллин

4) *күч.* Яшь буын. *Безнең үрентеләр – балалар, балаларның балалары...* Н.Әхмәдиев

**ҮРЕНТЕЛЕ** *с.* Үрентеләр җибәргән. *Кыска үрентеле басу беткәч, алда икенче төрле басу күренде.* Н.Фәттах. *Габдрахманның шундый зур кичерешләр белән жиңеп тапкан зәгыйфь үрентеле бәхете, тиздән тапталган нәфис чәчәк кебек, бөтен табылган гүзәллекне юкка чыгарырга сәләтле замана машинасы һәм империя албастысы табаны астында калып юкка чыгачак.* Р.Рахмани

**ҮРЕНТЕЛЕК** *и.* Орлыклардан үренте үстерү өчен махсус урын яки җайланма; парник

**ҮРКӘН** *и.* 1) Кавын, карбыз, кыяр кебек үсемлекләрнең озын сабагы

2) *тар.* Җир үлчәү өчен махсус бау, киндерә

3) Ун сажин (20 м) чамасы озынлык берәмлеге

**Ү́Р КУЯНЫ** *и. зоол.* Куяннар ыругыннан, гадәттә ялан җирләрдә тереклек итә торган, җәен соры, коңгырт төсләрдәге эрерәк гәүдәле куян; *русчасы:* **русак**. *Үр куяннарының гадәтен ул укып та, ишетеп тә белә.* Ф.Садриев. *Ләкин хәтта үр куянының да җитезрәге, хәйләкәре бүре тырнагыннан качып котыла ала.* А.Хәсәнов

**ҮРЛӘТҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **үрләү**. *Бу дөньяның, түрә булырга дип, Күптән хыялланган бер ире: Мин, ниһаять, хәзер зур начальник: Йөрәк бүлегенең мөдире! Мин буйсынып йөргән чиновниклар Кирәк тапмадылар сүземне. Көтеп-көтеп, өскә үрләтмәгәч, Билгеләдем үзем үземне!* И.Юзеев

2) *күч.* Ут төртү. *Шуннан соң алар бакчага су сибәләр, берәр кирәк-яракны ясап я төзәтеп-рәтләп куялар, аннары, бер-берсенә булыша-булыша, самавыр үрләтеп җибәрәләр.* Р.Мирхәйдәров

3) *күч.* Арттыру, югары күтәрү. *Әйдә, Сәйфи, куала ун меңне. Юкса процент үрләтә башлыйм.* Т.Галиуллин

**Үрләтә башлау** Үрләтергә тотыну

**Үрләтеп җибәрү** Тиз арада үрләтү. *Әнә инде ул кичтән үк әзерләп куйган утыннарны мичкә тутырып, ут үрләтеп җибәргән, сыерны савып кереп, сөтен дә сөзеп куйган.* Ф.Мөслимова

**ҮРЛӘ́Ү** *ф.* 1) Үргә таба хәрәкәт итү, тауга менү. *Машина, авылны, Брежневка «Җиңү» ордены тапшырылу уңаеннан төзелгән таза ферма каралтыларын, акташ икмәк амбарларын артта калдырып, тауга үрләде.* А.Гыйләҗев. *Күп кенә савир һәм барсиллар, Идел буйлап үрләп, Иделнең сул ягына, Кама тирәсендә элегрәк килеп урнашкан болгарлардан көньяктарак урнашалар.* И.Хуҗин

2) Уылдык чәчер өчен, агымга каршы, елга үренә күпләп хәрәкәт итү (балык тур.). *И ул аста бакалар кычкыра, ул, мин сиңа әйтим, вак балык үрли, и ул, мин сиңа әйтим, тал песиендә кортлар гөжли.* М.Мәһдиев. *Кара сыртлы бу балыклар теге үрләп уйнаган чабакларны күрмәгән дә кебек кыланалар.* Т.Нурмөхәммәтов

3) Ялкын, ут чыгып, тиз арада янып китеп күтәрелү, чолгап алу. *Ялкын инде эчкә үрли.* Г.Әпсәләмов. --- *берьюлы өч төштә – келәт, сарай, өй нүешендә ут үрләде* ---. Н.Гыйматдинова

4) *күч.* Алга хәрәкәт итү. *Егылдык та торып бастык – бары алга үрләдек. Яздан – көзгә – яланаяк...* М.Мәһдиев

5) *күч.* Югары дәрәҗәгә ирешү өчен тырышу, өскә күтәрелергә омтылу. *Нәрсәдә соң яшәү яме? – Зур урынга үрләүдәме, Яну, көю, дөрләүдәме?* Ф.Яруллин. *Таһир үзен һәм әйләнә-тирәсендәгеләрне һәрдаим контрольдә тотканга, «сугу»га эчтән һәрвакыт әзер булганга гына карьерасы өскә үрли дә.* Д.Булатова

6) *күч.* Ирексездән башка килү; биләү. *Сәлимәләрнең капка төбенә килеп җиткәч, моңа кадәр батыр кыланган егетләрнең күңеленә шик үрләде: бәлки, кызлар шаярткан гынадыр?* Н.Әхмәдиев. *Яңгыр җебе буйлап үрмә гөлдәй үрли уйлар, үрли биеккә!* Р.Фәйзуллин

7) *күч.* Арту. *Этаж саннары белән 7–8 гә үрләп, киңлек, зурлык исәбе белән бөтен кварталлар өстен каплаган бу магазиннар, чынлап та, башны әйләндерәләр.* Г.Гобәй

**Үрләп алу** Тиз арада үрләү. – *Сез нәрсә?! – дип җикерделәр инде хакимиятикә үрләп алган Өтәләү Зарифларның уллары.* А.Хәлим

**Үрләп бару** Торган саен күбрәк үрләү. *Пушкин илә Лермонтовтан үрнәк алам, Әкрен-әкрен югарыга үрләп барам.* Г.Тукай. *Менә бит кая үрләп бара эшләр!* Ф.Хөсни

**Үрләп китү** Әкренләп үрләү. *Безнең өйдә ут яна, Аның мае елгада. Җемҗем итә, Җемелдәп китә, Шырпысыз үрләп китә.* Табышмак. *Өстәвенә Чәчәк бервакыт Таш астыннан бәреп чыгып, өскә – Кояшка үрләп киткән.* Р.Фәйзуллин

**Үрләп кую** Кинәт үрләү. *Әле меңнәр яктырачак балкып, Яктырачак сүнмәс маяк булып, Актарылган хәтер уйный калкып – Сүнә барган турдан үрләп куеп.* Ф.Яхин

**Үрләп тору** Даими, әледән-әле үрләү; әле, хәзер үрләү. *Гомернең өзлексез алга үрләп торуын Инсафның да һич сизәсе килми, әмма моңа күз йомып калырга да мөмкин түгел.* К.Тимбикова. *Шундый бер йөрәк булган – Гел янып, дөрләп торган. Ялкыннары көн һәм төн Күкләргә үрләп торган.* Ф.Яруллин

**Үрләп яту** *сөйл. к.* **үрләп тору**. *Анда, аныкы булырга тиешле түгәрәк өйдән, күккә шәбәеп төтен үрләп ята иде.* Н.Фәттах

**Үрли башлау** Үрләргә тотыну. *Түгәрәктән сикереп чыгып булмый: Һәркем тырыша өскә, Үргәрәк. Егылып төшә, Янә үрли башлый...* М.Шабаев. *Менә юлны урталай кисеп, саран гына саркыган суы белән җирне юешләтеп яткан Тукмак кулы чишмәсе аша чыккач, юл тауга таба үрли башлады.* А.Хәлим

**Үрли бирү** Бернигә карамый үрләү. *«Кеше, син боларны миңа нигә сөйлисең?» – дигәндәй, ялкын үз җаена үрли бирә.* Р.Фәйзуллин

**Үрли тору** Эзлекле рәвештә үрләү. *Яңгыр белән аралашып, кояш Нурны мул яудыра. Яшел төсен аклап, һаман өскә Дөнья үрли тора.* Н.Мадьяров

**Үрли төшү** Бераз үрләү. *Гәп бераз үрли төшкәч, якыннанрак танышу башланды.* А.Расих

**ҮРЛЕ** *с.* Үзендә үр булган. *Чакрым чамасы үрле җир узганнан соң, яңадан өч-дүрт чакрым – сөзәк юл.* Ә.Баян. --- *бу болын, башкаларыннан аермалы буларак, үрге, үрле урында, бераз калку җирдә урнашкан.* Ф.Гарипова

**ҮРЛЕ-КЫРЛЫ** *с.* Тигез һәм үрле урыннары алмашып килгән, әле үр, әле тигезлек. *Кызулык аңа куркыныч түгел, кечерәк басым көченә ул җәйләнгән, үрле-кырлы җирдән йөри белә.* А.Азимов

◊ **Үрле-кырлы сикерү** 1) Тоташтан төрлечә сикерү; төрле якка чайкау. *Шул озын буйлы Миннәхмәт, яшь атның иреннәрен ерта язып, авызлык кидерде. Бирешәсе килмичә, һаман үрле-кырлы сикереп каршы торды Акъял.* В.Имамов; 2) Берәр сәбәптән (шатлану, борчылу һ.б.ш.) нишләргә дә белмәү, үрсәләнү, тыпырчыну. *Ә берчакны минем атым үлде, Карчык елый, карчык үкерә, Атсыз нишләрбез, ди, чәчен йолкый, Үрле-кырлы, малай, сикерә...* Һ.Такташ. *Янган йөрәк тә азрак басылыр, минем хикәяне укыса, Р. да үрле-кырлы сикерер һәм гомере буена үкенеп яшәр сыман иде.* В.Нуруллин.

**Үрле-кырлы килү** *к.* **үрле-кырлы сикерү**. *Хәсәнә абыстай бөтенләй коелып төште, үрле-кырлы килеп, үзен үзе өзгәләп ташлар чиккә җитте ---.* С.Поварисов. --- *болар яшәгән йорт диңгездәге гарасат-давыл уртасында калган кораб кебек үрле-кырлы килә, диварлар ярыла, өй эчендәге барча җиһаз-байлык җен кузгаткан сыман почмактан почмакка шуып йөри иде.* В.Имамов

**ҮРМӘ** *с.* **1.** 1) Үреп эшләнгән. *Аның төпкә табарак бөгелеп төшкән үрмә алтын беләзеге кулына матур бер шәүлә төшерде.* Г.Исхакый. *Нишләпләр соң, ни сәбәптән соң шушы киемнәрдән туй тантанасына әзерләнеп йөргән кәләш газ плитәсе янында, үрмә артлы урындыкка утырып, җан тәслим кылган?* К.Булатова

2) *к.* **үрмәле**. --- *карт утырткан үрмә гөлләр, койма-диварларга сарыла-сарыла, йортны чәчәккә күмде.* Г.Әдһәмова. *Йорт стенасы үрмә агачлар белән капланган: бары тик тәрәзә урыннары һәм кабан башлы герблар гына ачык калган.* Р.Вәлиев

**2.** *и. мәгъ.* 1) *к.* **үрем**. *Ачык ишектән сиздермичә генә кергән Сәрия идән уртасына басып сайраган Фәрдәнәнең чәч үрмәсеннән умырып тотты.* Н.Гыйматдинова

2) Челтәр. *Еылым үрмәсенең аякларына уралуын тойды.* Г.Гыйльманов

3) Үреп ясалган җәймә, япма ише нәрсә. *Су сибәргә килгән хатыннар, бергәләп, электән үк әзерләнеп куелган чыпталар, үрмәләр, әрекмәннәр белән яшелчәләрне ябып чыктылар.* А.Алиш

**ҮРМӘКҮЧ** *и. зоол.* 1) Үрмәкүчсыманнар классыннан вак бөҗәкләрне пәрәвез үреп аулый торган җан иясе. *Чебеннәрнең ай-яй зәһәр чагы, Үрмәкүчләр чигә пәрәвез. Йолдызларның күзен чекерәйтеп, Октябрьгә кереп барабыз.* Н.Әхмәдиев. *Үрмәкүчләр – бик борынгы хайваннар ---.* Биология.

2) *күч.* Каты күңелле кеше; башкалар хезмәтен куллана торган кеше. – *Шул үрмәкүчләр инде безнең канны суырдылар, – диде карт ---.* Г.Әпсәләмов

**ҮРМӘКҮ́Ч ОЯСЫ** *и.* Пәрәвез. *Әнә үзең дә күрәсең: ул – үрмәкүч оясы, таш стена түгел, әнә аз гына җилгә дә селкенеп торадыр.* Г.Тукай

**ҮРМӘКҮ́ЧСЫМАН** *с.* Үрмәкүчкә охшашлы; үрмәкүч кебек. *Кайбер коры җир ташбакаларының озынлыгы ун сантиметрдан артмый. Мәсәлән, үрмәкүчсыман ташбака.* Хайваннар дөньясы

**ҮРМӘКҮ́ЧСЫМАННАР** *и. күпл. зоол.* Буынтыгаяклылар тибыннан үрмәкүчләрне, чаяннарны, талпаннарны берләштергән класс. *Барлык үрмәкүчсыманнарның да дүрт пар йөрү аяклары бар.* Биология. *Бөҗәкләрнең тәпиләре бик эләгүчән, ә үрмәкүчсыманнар бик тә кечкенәләр, шуңа сез тәнегез өстеннән нидер үрмәләгәнне сизмәячәксез дә.* Туган як

**ҮРМӘЛӘ́Ү** *ф.* 1) Җир, кәүсә һ.б.ш. яссылык өстендә умырткалыкның ян борылышлары һәм кабыргаларның түбәнге очлары ярдәмендә боргаланып хәрәкәт итү. *Уткәргәч караңгы төнне, шул билгеләнгән беркөнне ерткычлар койрык алырга карт имән янына барырга юлга чыкканнар, кайсы үрмәләгән, кайсы йөгергән, кайсы чапкан.* А.Алиш // Очлыклары күп булган кайбер вак хайваннар, бөҗәкләр тиз-тиз хәрәкәт итү. *Инде көнозын кояш астында яткан «курчагы» өстенә кырмыскалар үрмәләгән, чебен-черки, башка бөҗәкләр кунган.* А.Хәсәнов

2) Дүрт аяклы хайваннар шикелле хәрәкәтләнү, мүкәләү. *[Рәхмәт] Мәчедәй үрмәләп, сумка янына бара.* А.Гыйләҗев. *Җиләкле җирләргә чыктым, япмадай кызыл җиләк. Утырып, чүгеп, үрмәләп, Тутырып җыйдым бер чиләк.* Г.Ибушев // Гәүдәне җирдән, берәр өслектән күтәрмичә хәрәкәтләнү; шуышу. *Яралыларны үрмәләп булса да бер тирәгә ташый башлагыз.* З.Мәхмүди

3) Куллар, аяклар белән ябышып, югарыга менү. *Физкультура дәресендә Сикерәбез, йөгерәбез – Коеп куйган көнгерә без. Аркан буйлап үрмәлибез, Маймыл яки шүрәле без ---.* Л.Шәех. *Аннан кичке якта гына кайтабыз да, өй эшләрен әзерләгәч, үзебезнең яраткан урыныбызга – печәнлеккә үрмәлибез.* И.Диндаров // Акрын гына өскә таба хәрәкәтләнү. *Машина ташлы-сикәлтәле юлдан тауга таба үрмәләде.* Д.Булатова

4) Берәр нәрсәгә ябышып, уралып үсү. *Тәрәзәдән тәрәзәгә Үрмәли үрмә гөлем. Гөлләр кебек матур булсын, Әлмәт, алдагы көнең.* К.Булатова. *Аның чәчкә-гөлләр үстергән балконына тиеп торырлык итеп, зифа тополь үрмәләячәк.* Л.Хәмидуллин

5) Биегәю, күтәрелү, сузылу. *Дулкыннар, ишелеп-ишелеп, болытларга үрмәләделәр.* М.Җәлил

6) *күч.* Көч-хәл белән хәрәкәт итү. *Көздән калган кылганнар белән тамак ялгарга дип тау башына ач колхоз атлары, кешеләрнең сыер-башмаклары үрмәләделәр.* З.Зәйнуллин

7) *күч.* Әкрен генә, ләкин үҗәтлек белән югары урыннарга омтылу. *Фазыл инде башка кешегә әйләнгән, ниндидер юллар белән партиягә дә үрмәләгән.* Г.Ибраһимов. *Син хәзер ярышлардан кайткансыңдыр инде, уңышлар ничек? Мастерлыкка үрмәләп буламы?* А.Гыйләҗев. *Түрә түргә үрмәләр, нәфес малга үрмәләр, гарьсез данга үрмәләр, Иблис җанга үрмәләр.* Г.Морат

8) *күч.* Акрынлап берәр нәрсәнең өстен каплап, томалап алу. *Күк йөзен коточкыч кара төтен каплап алган, кызыл ут ялкыннары күккә үрмәли.* Д.Каюмова // Берәр нәрсәнең өслегендә барлыкка килеп җәелеп китү. *Данир каушап калды. Бит алмаларына алсулык үрмәләп, борын очының тирли башлавын тойды.* Г.Әдһәмова

9) *күч.* Күчү, таралу. *Цензура тәрәзәләре ачык дип эчке цензура очсызлангач, ни хәл итәсең, тормыш сәхнәсенә дә, эстрада сәхнәсенә дә үзгәрешләр үрмәли дә үрмәли.* Н.Гамбәр

10) *күч.* Барлыкка килеп, тулысынча биләп алу (уй, хис тур.). *Минем күңелгә дә салкын, шомлы уйлар үрмәләп керә башлады.* Г.Гыйльманов. *Шушы боз салкынлыгы җанына үрмәләде.* М.Кәбиров

11) *күч.* Акрын гына бару. *Уку да алга үрмәли. Бишлегә генә укыйм.* А.Гыйләҗев

12) *күч.* Якынлашу. *Җир йөзендә күпме хатын-кыз ялгызлыктан интегә, яшем кырыкка үрмәләгәндә, шулар төркеменә мин дә кушылырмын да сан арттырырмын дип кем уйлаган!* Н.Гыйматдинова

◊ **Үрмәләп булса да** Ничек тә, көчхәл табып. *Теге бердәнбер көнне үрмәләп булса да киләсе калган икән миңа, дидем.* А.Тимергалин. **Үрмәләп дигәндәй** Көч-хәл белән, авырлык белән. *Кайдадыр валидол төймәсе барлыгын исләп, үрмәләп дигәндәй барып, тартмаларны актаргалады.* К.Кара

**Үрмәләп алу** Тиз арада үрмәләү. *Кантон шәһәрендә ачылган «Союзкож» тире җыю бүлегенә агентлар кирәк дигәч, Һашимов дус-иш аркылы анда да үрмәләп алды.* А.Алиш

**Үрмәләп тору** Даими, өзлексез үрмәләү. *Идел-йортка төрле яклап явыз айналар, шымчылар үрмәләп кенә торалар.* А.Гадел

**Үрмәли бару** Һаман үрмәләү; бернигә карамый үрмәләү. *Аның Рөстәме дә, ай-яй, егет! Забойдан һаман югарыга үрмәли бара.* Һ.Такташ. *Ә икенче аягына һаман көчлерәк булып суык үрмәли бара, ахырда ул аяк бозга ябышып, таш булып туңа.* Ш.Маннур

**Үрмәли башлау** Үрмәләргә тотыну. *Ул тир ачысыннан сызлаган күз тирәсен пычрак кул аркасы белән уа-уа мүкәли, үрмәли башлады.* А.Гыйләҗев. *Тагын үтә атна-айлар. Чүпрәкләр арасыннан чыгып үрмәли башлый бала.* К.Җәмит

**Үрмәли тору** Әлегә үрмәләү. *Сез тырмашкан арада, без, гадәттәгечә, югарырак үрмәли торыйк булмаса.* Р.Мөхәммәдиев. *Сукмак буйлап үрмәли торгач, кырмыска бик зур амбар янына килеп чыккан.* Р.Вәлиев

**Үрмәли төшү** Бераз үрмәләү. *Кайда чүгәли, кайда үрмәли төшеп, тар коридор буйлап ары уздык.* Р.Мөхәммәдиев

**ҮРМӘЛӘЧ** *и. зоол.* Үрмәләч кошлар семьялыгыннан азык эзләгәндә агач кәүсәсеннән, ботакларыннан үрмәләгән шикелле йөгереп йөри торган кош; *русчасы:* **поползень**. *Тамырлардан менә ябалдашка, Үрләп менә чыпчык – үрмәләч. Тик кояшка менеп җиталмас ул, Җирдә яшәп, Җирне күрмәгәч.* В.Фатыйхов

**ҮРМӘЛЕ** *с. бот.* Нәрсәгә дә булса үрмәләп, үрелеп үсә торган. *Җәй көне бакчамда үрмәле гөлләр үстерәм.* Г.Әпсәләмов. *Степан Петровичның бүлмәсеннән кечкенә генә верандага чыгып була, аңа безнең якларда үсми торган үрмәле яшел агач уралган.* М.Маликова

**ҮРНӘК** *и.* **1.** 1) Берәр нәрсәне карап, чагыштырып эшләр өчен өлге. *Галимнәр әйтүенчә, мода бу дәвердә Казаннан килә: Себер татарлары Идел-Урал татарларыннан хатын-кыз күлмәкләре үрнәкләрен, читекләр, күн туфлиләр, калфаклар, ирләрнең кайбер төр баш киемнәре үрнәкләрен кабул итеп алалар.* Д.Исхаков. *Әйе, әйе, нәкъ менә Шакирҗан Таһиров рус генетик алфавитын каллиграфик яктан эшкәртә, һәм бу безнең гасыр башында ук иң уңышлы язу үрнәге булып исәпләнә.* М.Глухов

2) Чигү, туку өчен бизәкләрнең рәсеме, өлге, күчергеч. *[Бибинур:] Әсма абыстай, карап туйыйк инде [казан сөлгесен]. Бигрәк матур икән. Үрнәкләрен өйрәнеп калыйк дибез.* К.Тинчурин

3) Җөмләдә сүз барган нәрсәгә китерелгән мисал. *Аның бу китабында мул очраган гыйбрәтле сүзләрдән берничә үрнәк китерик.* А.Тимергалин. *Сурәтле сәнгатьнең сатира һәм юмор характерындагы үрнәкләре «Чаян» журналында басыла килде.* К.Гыйззәтов

4) Үз ишендәге әйберләрне күзалларга мөмкинлек бирә торган бер әйбер. *1976 елның 19 августында совет ракетасы «Луна-24» Айдагы Кризислар диңгезе дигән урыннан грунт үрнәкләре алып өйгә – Җиргә таба юл тотты.* А.Тимергалин. *Музейларда ул үрнәкләр, Аллага шөкер, җитәрлек әле.* Б.Рәхимова. *Ул даруны кичекмәстән аңардан үрнәк өчен бер-икене алырга кирәк.* З.Хәким

5) Берәр нәрсәнең схемасы, тәртибе. *Мин эшемнең һәр үрнәген язып тордым аңарга.* М.Җәлил

6) Берәр нәрсәнең типик чагылышы булган нәрсә яки зат. *Тормышта, хезмәттә башкаларга үрнәк булырга кирәк иде.* М.Хәсәнов. *Авылда бу гаиләне яраттылар, үз иттеләр, үрнәк итеп күрсәттеләр. Сабырлык, сөю үрнәге итеп куйдылар.* А.Нәҗми

7) Башкалар тиңләшерлек яисә гыйбрәт алырлык зат, әйбер, күрсәткеч. *Син кояштан үрнәк алсаң, иҗтиһад итсәң һаман, Күп арасында кояш күк ялтырарсың берзаман!* Г.Тукай. *Әлеге шул акыллы булуы, сабырлыгы, иң кыен чакларда да, югалып-каушап калмыйча, дөрес, гадел карар кабул итә алуы белән ул безнең барыбыз өчен дә үрнәк иде.* В.Нуруллин

**2.** *с. мәгъ.* Үрнәк (*6 мәгъ.*) булырлык; үрнәк булып торган. – *Шәһәрдә даны таралган үрнәк тулай торак нинди була икән ул дип кенә кергән идем, – диде Тараканов.* А.Хәлим

**ҮРНӘКЛЕК** *и.* Үрнәк буларак, экспонат итеп куелган әйбер

**ҮРНӘКЧЕ** *и.* Декоратив бизәкләр төшерүче; рәссам-сызымчы. *Үрнәкчедән күрмәкче*

**ҮРСӘЛӘНҮ** *ф.* 1) Хәсрәттән нишләргә дә белмәгәнгә борчылу, пошыну. *Ярар, җәмәгать, тынычланыгыз, ул кадәр борчылыр урын юк әле! Син дә алай бик үрсәләнмә, Маһисәрвәр апа!* В.Нуруллин. *Фәритенең тирә-якта булган гаделсезлекне, башбаштаклыкны, талаучыларны күреп җаны әрнеде, үз-үзенә урын таба алмый үрсәләнде.* К.Кара

2) Шатлыктан сикергәләү, боргалану. – *Кил монда, кил, пес-пес-пес! – Мәче, үрсәләнеп, битемне яларга керешә.* З.Мәхмүди

**Үрсәләнә башлау** Үрсәләнергә тотыну. *Һәм мин эзлим караңгылык чыганагын. Нигә эзлим? Ниемә ул кирәк? Һәм кайдадыр үземдә чыга янгын һәм сулкылдап үрсәләнә башлый йөрәк.* Р.Харис. *Яшьлек җырларын артык хискә бирелеп тыңларга куркам – тынычлыгым кача, күңелем читлектәге кош сыман үрсәләнә башлый.* М.Яһудин

**Үрсәләнә бару** Торган саен күбрәк үрсәләнү. *Ишек уемына якынлашкан саен үрсәләнә бара йөрәк.* М.Әмирханов

**Үрсәләнә бирү** Бернигә карамый үрсәләнү

**Үрсәләнеп алу** Бераз гына үрсәләнү. – *Оланымны быел күрә алмыйм икән инде болай булгач! – дип, әни үрсәләнеп алды.* Х.Сарьян

**Үрсәләнеп йөрү** Озак вакытлар үрсәләнү. *Бала өчен үрсәләнеп йөрү. Кергә алырмы икән?* Ю.Әминов

**Үрсәләнеп кую** Бераз үрсәләнү *Шулай да аның җаны вакыт-вакыт үрсәләнеп куя, һәм алай үрсәләнгән минутларда малай әледән-әле тәрәзәгә күз салып ала иде.* Ф.Хөсни

**ҮРТ** *и.* 1) *иск.* Язын кар астыннан чыккан корыган үләнгә төрткән ут. *Авыл тирәли каудан үләнгә үрт салсыннар.* Л.Зөлкарнәй. *Гаҗәпләнеп карап торам кайчак Үрт яндырып киткән камышны, Кайберләре калган ут та тими, Бер Ходайның шундый язмышы.* З.Ишбирде

2) *диал.* Йорт-җирне ялмап алып яна торган ялкын

**ҮРТӘВЕЧ** *и. фольк.* Кемне дә булса үртәү өчен чыгарылган такмак. *Лирик әсәрдә үртәвечләрнең кулланылуы жанрның бүгенге көндә дә яшәп килүенә дәлил булып тора.* Фәнни Татарстан. *Уеннар ярдәмендә балаларга милли йолаларыбызны, бәйрәмнәребезне такмаклар, табышмаклар, үртәвечләр белән ирештерсәк, алар онытылмас, гасырлардан гасырларга күчеп дәвам итәр, мәңге сакланыр, милләтебез исән булыр.* Биектау хәбәрләре

**ҮРТӘГЕЧ** *с.* Үртәндерә, гарьләндерә торган. *Җанын туктаусыз нидер кимергән кыяфәттә йөрүче Ибраһимовның үртәгеч карашын янә тоеп, тәненә салкын йөгерде.* Ф.Сафин

**ҮРТӘКӘ** *и. тар.* Гадәттә, озын юлга чыгучылар амулет, бөти итеп йөрткән тәкә сыны. --- *ул, күл төбеннән чыккач, агач уенчык – үртәкәсе белән уйнап мавыга.* Р.Әхмәтьянов

**ҮРТӘЛӘ́Ү** *ф. сөйл.* Үртәү, үчекләү. *Иңнәремә салып кайнар кулын, Язгы кояш назлап иркәли. Утлы карашлары, чагылдырып, Күзләремне минем үртәли.* К.Фатыйхова-Бәдретдинова

**ҮРТӘЛҮ** *ф.* 1) Күңелгә авыр алу, гарьләнү, кимсенү. *«Үрдәк» диеп атадылар безне, Әллә күлдә оста чумганга... Бик үртәлә идем: әнкәем дә, Мин үзем дә «үрдәк» булганга...* И.Юзеев. *Хатын, чарасызлыктан үртәлеп, үксеп елап җибәрде.* Г.Әдһәмова

2) *сөйл.* Ярсу, нәфрәтләнү. --- *Җаек шәһәрчегенең тез чүкмәвенә үртәлгән Пугачёв февраль уртасында Бирдәдән тагын Җаекка юнәлә.* В.Имамов. *Ни өчендер дөньяга үртәлеп яши бу хатын.* Г.Гыйльманов

**Үртәлә бару** Торган саен ныграк үртәлү. *Торган саен ныграк үртәлә барган Утамыш та кинәт тынып калды.* Н.Фәттах

**Үртәлә башлау** Үртәлү билгеләре сизелү. *Башлык бәндәнең канәгатьсезлектән үртәлә башлавы инде йөзенә*

*бәреп чыкты.* В.Имамов. *Хәлимнең үртәлә башлавын күреп, Митри карт шундук йомшады.* Г.Гыйльманов

**Үртәлә бирү** Азрак үртәлү. *– Әлбәттә, шау-шу тудырыр өчен, – диде Хәлил, энесенең башсызлыгына үртәлә биреп.* М.Кәбиров

**Үртәлә төшү** Бераз үртәлү. *– Син әллә чынлап та сәеррәксең, абзый, әллә башыңны диванага саласың, – диде шеф, үртәлә төшеп.* Д.Булатова

**Үртәлеп алу** Берара үртәлү. *Сөенәсе чакта дуслар уңышларга, Көнләшеп тә куя кайчакны, Усаллана, Бер үртәлеп ала...* Ф.Яхин

**Үртәлеп бетү** Бик нык үртәлү. *Кәримә үртәлеп бетә. Ярыймы инде кешенең күңеле ачылган минутта өстенә килеп басарга?* Ф.Яхин

**Үртәлеп йөрү** Озак вакытлар үртәлү. *Мондый хәлгә Гөлназ балачактан ук үртәлеп йөри.* И.Нәбиуллина

**Үртәлеп кую** Кыска вакытка үртәлү. *Кайчакта үртәлеп тә куям: – Балачага кебек, бишле чалгы тоттырып... – дип киреләнәм.* Г.Әдһәмова. *Ул ялгышкач борчылам, үзем ялгышкандай үртәлеп куям.* И.Нәбиуллина

**Үртәлеп тору** Әле, хәзер үртәлү. *Кунаклар гына түгел, моңарчы Турай чәчәнгә күрәләтә ачуы килеп, үртәлеп торган яшь чәчән дә сагая калды.* Н.Фәттах

**ҮРТӘНДЕРҮ** *ф.* 1) *йөкл. к.* **үртәнү**. *Минем бу сүзләрем Динаны чын-чыннан үртәндерде ---.* М.Хәсәнов

2) *з.-сыз* Үртәнергә туры килү. *Хаксыз сүзләр үртәндерә*

**ҮРТӘНҮ** *ф. к.* **үртәлү**. *«Ник мин аны судка бирмәдем икән?» – дип үртәнеп уйлады Арслан.* Г.Ахунов. *Әти үзенең әле генә күренеп алган йомшаклыгы өчен хәзер үзенә үзе ачулана, хатынкыз юатыр көнгә калуына үртәнә иде.* Г.Бәширов

**Үртәнә башлау** Үртәнергә totыну. *Арчаның хакимият башлыклары да яңгырның кирәк түгел чакта, уч иткәндәй, коярга тотынуына инде үртәнә үк башлаганнар иде ---.* Г.Ахунов, М.Гәрәев

**Үртәнә бирү** Бераз үртәнү. *Солтан, сүзнең асылына һаман барып җитә алмаганга үртәнә биреп, өзеп сорады: – «Мулла бирәме сезгә атны, юкмы?»* Г.Ахунов

**Үртәнеп бетү** Бик нык үртәнү

**Үртәнеп йөрү** Озак вакыт үртәнү

**Үртәнеп кую** Бер тапкыр үртәнү. *– Әле бит теге көнне педагогларны сүлпәнлектә гаепләгән булды, – дип, үзалдына үртәнеп тә куйган иде.* Г.Ахунов

**Үртәнеп тору** Әле, хәзер үртәнү

**ҮРТӘНЧЕК** *с.* Тиз үртәнә, үрсәләнә торган. *Үртәнчек кеше тиз картая, ди.* Мәкаль

**ҮРТӘ́Ү** I *ф.* 1) Ут төртеп, тоташ яндыру

2) Үчекләп үртәндерү, яманлап, хурлап һ.б. гасабиландыру, гарьләндерү, берәүдән көлү. *Газинурны яратып бетермәгән, Әлфия алдында оятка калдыруын бер генә минутка да исеннән чыгармаган Сәлим үртәп көлүдән тыела алмады.* Г.Әпсәләмов. *Әле мине гел Хыялый Хыял Хыялович дип үрти идең!* Г.Каюмов

**Үртәп алу** Тиз генә үртәү. *Сыртында тик утыру туйдыра башласа, сикереп төшәм дә үгезне тагын үртәп алам.* Н.Әхмәдиев. *Айбулат та Нәҗибәне үртәп алырга булды.* Т.Әйди

**Үртәп бетерү** Бик нык үртәү, үртәп үзәккә үтү. *Күрше егетләренә тикле җанын кытыклап үртәп бетерде.* Х.Хәйруллин

**Үртәп йөрү** Озак вакытлар үртәү. *Берсен кочаклап ал да, мин риза, әйдә, кайтабыз, дип әйт – кайтмаячаклар. Кабат берсе дә сине үртәп йөрмәячәк.* Р.Газиз. *Үземне белгәннән бирле безнең Асаба авылы кешеләрен тирәяктагылар «Ухарь-купич» дип үртәп йөрделәр.* И.Диндаров

**Үртәп килү** Әлегә кадәр үртәү. *Тормышның бер ягы Рәсимәне гел үртәп килде.* Г.Әдһәмова

**Үртәп кую** Бер тапкыр үртәү. *«Кайда соң синең баш-аягың» – дип, эченнән генә үртәп куйды Газинур.* Г.Әпсәләмов. *Гамбәрия, иренен кыйшайтып, мине үртәп куйды: – Нургаличек, имеш!* Д.Зөбәерова

**Үртәп тору** Даими яки әледән-әле үртәү; әле, хәзер үртәү. *Яшьлек һаман үртәп тора, матур кызлар күрсәтеп!* Ш.Галиев. *Утны үртәп тора өлгер заман җиле, Бер кузгалып китсәм, инде кайтмам кире.* В.Ильясов

**Үрти башлау** Үртәргә тотыну. *Малайлар күрсә үрти башларлар!* А.Гадел. *Артист үрти башлагач, Ханзафаров бу язуларын ташлады, әмма хәзер шул дәфтәрен тапмагач, мөгаен, чәлдергәннәрдер, дип коты очты.* Г.Әпсәләмов

**Үрти бирү** Бернигә карамый үртәү. *Ә теге күсәк, билләренә таянган хәлдә: – Бар, бар, әниеңә кайтып әйт... – дип үрти бирде.* Ф.Яхин

**Үрти тору** Әлегә үртәү. *Үрти торгач, тәки күзен кызыктырганнар икән!* Ф.Яхин. *Син бар, тегене үрти тор, калганын үзебез эшләрбез.* Шәһри Казан

**Үрти төшү** Тагын да үртәү. *– Ай, сөйләп торасың тагын. Үпкән кеше диярсең, – диде Катифә, аны тагы да үрти төшеп.* Р.Сибат

**ҮРТӘ́Ү** II *и. к.* **үртәвеч**. *Җырлардан, бәетләрдән, акиятләрдән, риваятьләрдән, мәкальләрдән, табышмаклардан кала, монда сөйләм ситуациясенә караган (сөйләм аша тормышка ашырылган) жанрлар да бар: тапкыр җавап, үртәү, такмазалар.* Г.Рәхимов

**ҮРҮ** I *ф.* 1) Бау, киндерә, пеше чыбык кебек әйберләрдән аларны тезеп, аралаштырып, чалыштырып, нәрсә дә булса ясау. *– Күрмисезмени, камыш намазлык үрәм, – диде карт ачулы гына.* М.Галәү. *Арзу чәчен икегә үреп салса, Кәримә дә үзенең тәрәшлесен икегә аерып тарый...* А.Гыйләҗев. *Нииндидер өмә, имеш. Читән үрәләр.* А.Хәлим. *Үрмәкүч пәрәвәзне бөҗәк аулар, оя ясар өчен үрә.* Маяк

2) *к.* **ишү**. *Телим икән – Суларыңа ялкын өрәм, Ялгышлардан-язмышлардан Аркан үрәм.* М.Шабаев. *Нәселем минем өзелерлек түгел, Мең яшәгән ныклы тамырдан, Чулман буйларында иген иккән, Суга юкә салган, бау үргән.* И.Юзеев

3) *күч.* Аерым өлешләрне бер-берсенә бәйләп, бербөтен хасил итү. *Эльмираның үзенә генә хас бер үзенчәлеге бар: ул балалар дөньясын искиткеч органик-табигый рәвештә зурлар тормышы белән бергә үреп бирә белә.* Б.Рәхимова. *Фәлсәфәгә, сурәтләү чараларына, гомумиләштерүләргә бай булуы, яңа һәм традицион шигырь формасын уңышлы үрә белүе аны бу өлкәдә чын шагыйрь буларак таныта.* Л.Минһаҗева

**Үрә бару** Бер-бер артлы үрү. *Кеше уйларын табигать манзарасы белән үрә бару аның фикер сөрешенә яшәү көче бирә, әсәрне ләззәтләнеп укыр тәм өсти.* Кызыл таң

**Үрә башлау** Үрергә тотыну. *Син камышка барып килерсең, ә мин ул арада казыклар кагып, шалаш читәнен үрә башлармын.* М.Галәү. *Йокысыннан уянуга, Үрмәкүч челтәр үрә башлаган.* А.Имамиева

**Үрә килү** Әлегә кадәр үрү. *Шигърияттебездә тормыш үзе үрә килгән буыннар чылбыры исән-иминме соң?* И.Вәлиулла

**Үрә тору** Әлегә үрү; бер-бер артлы һаман үрү. *Без икәү үрә торыр идек*

*[чабатаны], Хәтирә апа базарга сатарга йөрер иде.* М.Галәү. *Үрмәкүч пәрәвезне үрә тора.* Т.Галиуллин

**Үреп алу** Тиз генә үрү. *Атасы белән атна-ун көн эчендә читән абзар үреп алдылар, үзләре сыладылар.* З.Зәйнуллин

**Үреп ату** Тиз-тиз, аннан-моннан үрү. *Мин һаман үсәм әле. Иртән торуга юынам, Тешләремне чистартам. Чәчләремне тарыймын да Тиз генә үреп атам.* Ф.Тарханова. *Чабатаны тиз-тиз үреп ата, безгә тезеп кенә барасы.* Безнең гәҗит

**Үреп бару** Рәттән, эзлекле рәвештә үрү. *Яңгырап торсын изге азан – Күкрәп яшә, шәһре Казан! Дан-шөһрәтне һәм михнәтне Дәверләргә үреп бардың. Милләт горурлыгы булып, Тарихларга кереп калдың.* Ф.Тарханова

**Үреп бетерү** Тулысынча үрү. *Люба йомшак кына итеп чәчнең очына чаклы үреп бетерде.* З.Кадыйрова. *Әле кичә генә, син чыгып киткәч, матурлыгыңны күреп, бер тәлинкә үрә башлаган идем, үреп бетергәч, үзеңә бүләк итәрмен.* А.Мансуров

**Үреп җибәрү** Җае белән үрү. *Урам буйга, читән урынына, текмә ясады, киң тактадан капка эшләтте, килешү буенча, Закирның капка баганасын төбеннән кисеп алып, ике уртага читән үреп җибәрде ---.* Г.Ибраһимов. *Әмирхан Еники текстка мул итеп яңа парлар үреп җибәрә.* Ф.Хатипов

**Үреп китү** Билгеле бер урыннан үрү. *Вакыйгаларны да үзара үреп китү белән мавыкмый.* Казан утлары

**Үреп кую** Алдан үрү. *[Үрмәкүч] Иртә таңнан торып, өйнең бер кыегыннан икенче кыегына кадәр пәрәвез үреп куя да һәр көнне офыктан нурларын балкытып килеп чыга торган Кояшны сагалый башлый, ди.* Г.Гыйльманов

**Үреп тору** Әледән-әле яки даими үрү; әле, хәзер үрү. *Ашыкмый йөреп тора, Ятьмәсен үреп тора. Чебеннәр күреп тора, Ятьмәгә кереп тора. Үрмәкүч.* Н.Әхмәдиев. *Әнә берсе, иң алда басканы, толымын бер сүтеп, бер үреп тора.* Г.Әпсәләмов

**Үреп чыгу** Башыннан ахырына кадәр үрү. --- *Р.Әхмәтҗанов --- шигырь жанрының теләсә кайсы биләмәләрендә виртуозларча иркен эш итә: шигырьләрнең озынын яки кыскасын булсын, менә диген итеп коеп куя, поэмаларны да оста үреп чыга, моңлы яки дәртле җыр текстларын да үзенчәлекле итеп яза.* Р.Фәйзуллин

**ҮРҮ** II *ф.* Үрентеләр чыгару, шыту, борнау. *Күңелләргә шомлы хәбәр салып, Икмәк үреп ята кырларда.* М.Шабаев. *Ай буена өзлексез яуган яңгыр аларның төпләренәчә үткән – көлтәнең өсте үрә, төбе чери.* Г.Гыйльманов

**Үрә башлау** Үрергә тотыну. *Корылык аркасында һәлак булган игеннәрдән тыш, көзге культуралар да юкка чыга – яңгырларга чаклы урдырылган игеннәр үрә башлаган.* Яңа Чишмә хәбәрләре

**Үрә төшү** Бераз үрү. *Суган да үрә төшкән инде*

**Үреп бетү** Бик нык үрү. *Базда бары орлыкка дип кадерләп саклаган, үреп беткән өч-дүрт бидерә чамасы бәрәңге калды да өй эчендә һич туя белми торган олы-кече өч-дүрт тамак калды.* Н.Фәттах

**Үреп килү** *к.* **үрә башлау**. *Уң якта, элекке күпер убылып, тирән чокыр хасил булган, черек бүрәнә калдыклары арасыннан каен, зирек үсентеләре үреп килә.* Д.Булатова

**Үреп китү** *к.* **үрә башлау**. *Тамырдагы арыш һәм бодай да урыны-урыны белән чәбәләнеп, башакларын жиргә терәп, үреп киттеләр.* М.Мостафин

**ҮРЧЕМ** *и.* 1) Үсемлек, хайваннар үрчүеннән барлыкка килгән артым, яшь буын. *Ә бит бу гөлләр бакчада үсмиләр, чәчәк атмый, үрчем бирмиләр дип, ничек шиккә салганнар иде.* А.Хәсәнов. *Үзе дә шул, минекеләр басмый, чебеш чыгарып биргәч, ярты үрчеме белән алып килермен, дип апкайтты да чуаркайны...* Т.Гарипова. *Бияләр колынлый, сыерлар бозаулый, сарыклар бәрәнли торган, ягъни мал-туарның үрчем вакыты.* Ф.Сафин

2) *күч. сөйл.* Күзгә күренерлек артым, алга китеш. *Эш үрчеме*

**ҮРЧЕМЛЕ** *с.* **1.** 1) Тиз үрчи торган; үрчеме күп булган. *Өченче ел Рәйсә, үрчемле нәсел дип, Кормашбаштан ана каз алып кайткан иде.* Р.Батулла

2) *күч.* Уңышлы, әйбәт нәтиҗә китерә торган. *Шул ук еллар – аның каләм тибрәтүенең дә иң үрчемле вакыты.* Ф.Галимуллин // Җиңел башкарыла торган, тиз бара торган; күп эшләнә торган. *Аның байтак елларга сузылган үрчемле хезмәте татар совет музыкасының үсешендә тулы гына бер дәвер булып санала ала.* М.Җәлил

**2.** *рәв. мәгъ.* Тиз, күп итеп, интенсив рәвештә. *Чыннан да, төзелеш бик үрчемле бара ---.* М.Маликова

**ҮРЧЕМЛЕК** *и.* **1.** Үрчемгә калдырылган хайван, кош-корт, үсенте

**2.** *с. мәгъ.* Үрчемгә билгеләнгән. *Үрчемлек көтүләр*

**ҮРЧЕМЛЕЛЕК** *и.* Үрчемле булу сыйфаты. *Имчәкләр саны хайван төренең үрчемлелегенә бәйле.* Биология. --- *әсәрләрнең үрчемлелеге җәһәтеннән ул кемнәрдәндер, бәлки, калышадыр да.* Ф.Хатипов

**ҮРЧЕМСЕЗ** *с.* **1.** Үрчеми яки начар үрчи торган, үрчеме, артымы булмаган. *Ләкин күңелегезне төшермәгез, сперматозоидлар бөтенләй булмаса гына, ир кеше чыннан да үрчемсез дип санала.* Ватаным Татарстан. *Тик мин гаделлек яклы. Тик мин генә, үрчемсез тавык сыман, вакытыннан алда картайдым, ахрысы...* Яшел Үзән

**2.** *рәв. мәгъ.* Үрчем китермичә. *Чөнки өч ел үрчемсез йөргәннән соң, көтмәгәндә-уйламаганда балага узуы аның өчен куаныч, хәтта бәхет, күрәсең.* Ә.Әминев

**ҮРЧЕМСЕЗЛӘНҮ** *ф.* Үрчемсез булып китү, үрчемсезгә әверелү

**Үрчемсезләнеп китү** Кинәт үрчемсезләнү

**ҮРЧЕМСЕЗЛЕК** *и.* Үрчемсез булу сыйфаты

**ҮРЧЕТКЕЧ** *и.* **1.** 1) Үсентеләр үстерә торган урын; питомник. *Дәүләт үрчеткечләреннән алынган үсентеләр күпкә ышанычлырак.* Яңарыш

2) *күч.* Нәрсәне дә булса арттыру, тарату чыганагы. *Кыйммәтле үрчеткечләрдән бик яхшы файдалану өчен, хайваннарны ясалма орлыкландыру кулланыла.* Биология

**2.** *с. мәгъ.* Үрчем калдырырга билгеләнгән; үрчергә ярдәм итә торган. *Умай – төрки мифларда үрчеткеч рух алиһәсе.* Казан утлары

**ҮРЧЕТҮ** *ф.* 1) Хайваннарны, үсемлекләрне үстерү, нәселен арттыру. *Шуннан бирле тал балалары Тәхаветдиннәр «Үрнәк» дигән авылда бердәм һәм дус булып яшиләр, балалар үстерәләр, мал-туар үрчетәләр, ди.* А.Хәлим. *Ш.Сафиуллин шушы күргәзмәдән яңа сортлы өч карлыган ботагы алып кайта, аларны үрчетеп, үзебездәге сортлар белән ялгап, тагын да югарырак уңыш бирә торган сортлар булдыру өстендә эшли.* Г.Мөхәммәтшин

2) *күч.* Нәрсәнедер арттыру, күбәйтү; ишәйтү. --- *әгәр берәү гыйлемне үстермәк теләсә, кайгы-хәсрәтне дә үрчетер – бу сүзләр Соломон патшаныкы.* А.Тимергалин. *Шул акчаны үрчетеп, мин ныклы, бай тормыш*

*корырга тиеш.* Г.Гыйльманов // Нөсхәләрен арттыру. *Кәгазь үрчетү*

**Үрчетә башлау** Үрчетергә тотыну. *Бервакыт безнең хуҗалыкка да тавык һәм үрдәк үрчетә башларга кушылды ---.* В.Нуруллин. *Борынгы чорларда ук мордвалар дуңгыз үрчетә башлыйлар, Казан ханлыгы чорында бу тармак тагын да ныграк үсә ---.* Б.Хәмидуллин

**Үрчетә килү** *к.* **үрчетеп килү**. *--- моңарчы аны республиканың татар авылларында да рәхәтләнеп үрчетә килделәр.* Шәһри Казан

**Үрчетеп алу** Билгеле бер вакыт аралыгында гына үрчетү; тиз арада үрчетү. *Югыйсә минем үрчетеп аласы кәгазьләр бар иде.* М.Маликова

**Үрчетеп җибәрү** Үрчетүгә керешү. *Кош-корт, каз-үрдәк асрасалар да, нишләптер олы мал үрчетеп җибәрәсе итмәделәр.* Г.Бәйрәмова

**Үрчетеп килү** Электән үрчетү; системалы рәвештә үрчетү

**Үрчетеп кую** Алдан ук үрчетү. *Исәбем куышта төн кунып, таң атаратмаста үз кишәрлегемне тегеләр узып китәлмәслек итеп алга үрчетеп кую иде.* Р.Мулланурова

**Үрчетеп тору** Даими үрчетү. *Шуңа да карамастан мин аларны тәрбияләп, үземчә сынаулар үткәреп, үрчетеп торам.* Ватаным Татарстан. *Аны туплый бел, кадерен бел, әрәм-шәрәм итмә, үрчетеп тор, мирас итеп калдырырлык булсын.* Шәһри Чаллы

**Үрчетеп яту** *сөйл. к.* **үрчетеп тору**. *Иң әйбәт җирдә кычыткан үрчетеп ята, адәм актыгы!* А.Гыйләҗев. *Ярамый безгә бөтен ишегалдын биләп, мал үрчетеп ятарга, дип, әти еш кына сукранып та ала.* А.Хәсәнов

**ҮРЧҮ** *ф.* 1) Нәселе арту, күп санда туу, ишәю. *Аллалар исән һәм көчле булганга, Җир йөзендә тереклек дәвам итә: агачлар, ашлыклар үсә, хайваннар үрчи, кешеләр үрчи.* Н.Фәттах. *Җәй урталарына ул күлләрдә маймыч балыклар үрчеп чыга.* Л.Хәмидуллин // Бер урында күп булып үсү; үсә-үсә таралу, зуррак урынны биләү. *Бакчаңда бетерсәң, аланнарда үсә, буш урын таба да тыгызланып үрчи, яңа орлыклар очыра! Тузганак.* Ш.Галиев. *Тигәнәкләр үрчи, чишмәләрне баса кыргый таллар.* И.Биектаулы

2) *күч.* Берәр нәрсә арту, ишәю. *Иртә торганның эше үрчи, төн йокламаганның юлы үрчи.* Мәкаль. *Акча дигәч Асафның да күз кызды, чормадагы «копилка»лары да үрчеми, тик ятып акча артмый ---.* А.Гыйләҗев

**Үрчеп алу** Берара үрчү. *Әмма безнекеләр: «Еланга ояларга ирек бирсәң, үрчеп алгач, муеныңа урала», – дип ашыкты.* С.Поварисов. *Бервакыт үрчеп алган карп балыкларына да халык тиз җитеште – берсен дә калдырмадылар.* Көмеш кыңгырау

**Үрчеп бару** Торган саен күбрәк үрчү. *Тормышлары җитеш, малтуарлары үрчеп бара.* Ф.Әмәк

**Үрчеп китү** Кинәт яки тиз темплар белән үрчү. *Озаклап дога укыдылар, яңа урынның бәрәкәтле, котлы булып, төяк итүчеләрнең монда исәнлектәсаулыкта яшәп, ишәеп, үрчеп китүләрен теләделәр.* З.Мурсиев. *Көнбатыш якларда халыклар нигәдер үрчеп китә алмагангадырмы, анда көнчыгыштан күчеп килгән кавемнәргә дә урын җитәрлек була икән.* И.Хуҗин

**Үрчеп кую** Көтмәгәндә, тиз арада үрчү. *Тик менә ул түрәләр кай арада кире үрчеп куя ---.* Безнең гәҗит

**Үрчеп тору** Даими үрчү; әле, хәзер үрчү. *Әледән-әле үрчеп торган байбак колонияләре – Азнакай төбәгенең, шушы тарафларда әүвәл-әүвәлтеннән гомер итеп, мул уңыш үстереп, күп итеп аяклы мал асрап яшәп яткан тырыш халыкның киерелеп бер мактана алырлык горурлыгы!* А.Хәсәнов. *Бүген күпме чегән хатыннары Күрәзәлек итә, алдалый. Йолдызнамәчеләр үрчеп тора. Ник ышана халык? Аңламыйм.* И.Гыйләҗев

**Үрчеп яту** *сөйл. к.* **үрчеп тору**. *Мин инде сине күреп, балаларыгызга шатланып, нәселем бетмәгән, үрчеп ята икән, дип куанып, үземнең туган җиремнең кара туфрагы булу исәбе белән, сезне үлепләр сагынып кайттым.* З.Зәйнуллин. *Сез анда үрчеп ятканда, мин эш дип яндым.* Д.Булатова

**Үрчи бару** Эзлекле рәвештә үрчү. *Урам көчекләре сыман көннән-көн үрчи барган сукбайлыкның тамырлары, – әлбәттә, беренче чиратта гаиләдә.* Д.Гыйсметдин. *Ике-өч баштан башланган эш җәелә барды, үрчи барды мал-туар, бүген үзләренең ялан зурлык фермалары бар.* К.Кара

**Үрчи башлау** Үрчергә тотыну. *Әнә кытайлар чыпчыкны кырып бетерделәр дә, басуларда корткыч бөҗәк үрчи башлагач, хәзер чыпчыкны чит илләрдән алтынга сатып алалар.* М.Галиев. *Аннары инде кызның көндәлегендә яңарак кына зур шатлык булган дүртләр урынына бишләр үрчи башлады.* З.Мурсиев

**Үрчи бирү** Бернигә карамый үрчү. *Гөрләп кенә яшисе借ләре, үрчи бирәселәре иде дә бит, бар илне тетрәтеп, Ватан сугышы кабынып китмәсә...* М.Рәфыйков. *Байбаклар безнең төбәкләрдә рәхәтләнеп үрчи бирәләр.* Ватаным Татарстан

**Үрчи тору** Өлегә үрчү; һаман-һаман үрчү. *– Анагыз хак әйтә: без кискән саен үсә торабыз, кискән саен үрчи торабыз! – диде Тал-Ата, күкрәген киереп.* А.Хәлим. *Буең озын, уең кыска, Алдашасың хәйран оста. Бар булмышың белән лаек Бу илдә син һәрбер постка. Шуңа да син бик көрсенмә, Утыра бир көрсиеңдә. – Дөрес булыр ялганың да, Үрчи торыр яраның да.* Г.Морат

**ҮРШӘН** *и. диал. к.* **ләтчә**

**ҮСЕМ** *и.* 1) Берәр нәрсәнең саны, микъдары үсү күренеше; үсү дәрәҗәсе. *Әгәр хаҗи бер сыерны илле сумга сатып, елына алты сумнан үсем алу исәбенә банкка салып куйган булса, шул акча банкта илле ел ятса, беләсезме, ул илле сум күпмегә үскән булыр иде?* С.Шәрипов

2) *иск.* Суүсем. *Июльдә елга өсте яшькелт зәңгәр үсемнәр белән каплана һәм балык тончыга.* Г.Паушкин

**ҮСЕМЛЕК** *и.* Гадәттә, туфрактагы һәм һавадагы органик булмаган матдәләр белән туклана һәм кислород бүлеп чыгара торган, тамыры белән җиргә береккән организм. *Дөньяда ул белмәгән үсемлек бик аз булыр, имеш.* Г.Кутуй. *Берәр юк кына үсемлек яки үләнне өзәргә үрелгәндә, бу үләннең Җир йөзендә соңгы бөртеге, бердәнбер экземплярын өзмим микән, дип сискәнеп куярсың.* А.Хәсәнов

**ҮСЕМЛЕКЧЕЛЕК** *и.* Авыл хуҗалыгының культуралы үсемлекләр үстерү тармагы. *1920 елдан башлап, нәшрият авыл хуҗалыгының аерым тармаклары буенча (үсемлекчелек, терлекчелек һ. б.) махсус кулланмалар чыгара башлый.* Т.Корбангалиева. *Болар барысы да безнең шартларда авыл хуҗалыгын топрыклы үстерүнең, терлек азыгын, яшелчә һәм башка төр үсемлекчелек продукциясен гарантияле җитештерүнең нигезе булып тора.* Г.Усманов

**ҮСЕНДЕРҮ** *ф.* 1) Иркәләп, мактап, кешенең күңелен күтәреп җибәрү. *Алар [сүзләр] җилкетә, алга әйди, үсендерә, шушы сүзләрдән соң яшәүнең мәгънәсен чамалаган сыман булды, күңел түреннән, җанны ымсынды-

*рып, ниндидер яктылык өермәсе үтте.* Ф.Сафин. *Гали паша әүвәл Бәхрәйнне, бераздан Кызыл диңгездәге барча порт-каланы португаллардан азат итеп, күңелләрне үсендерде.* В.Имамов

2) Мактанырга, масаерга мөмкинлек бирү, юл кую; азындыру. *Башыңа да менеп биер әле, Бик үсендер әле, үсендер...* Ә.Рәшитов. *Үзем боздым сине, үзем үсендердем...* В.Имамов

**Үсендерә башлау** Үсендерергә тотыну

**Үсендерә килү** *к.* **үсендереп килү**

**Үсендерә төшү** Тагын да яки бераз үсендерү. *– И-их, үгез дус, килде-китте аттан шәбрәк икәнсең ләса! – дип, Манчаровский үгезне тагын да үсендерә төште.* Ә.Баян

**Үсендереп алу** Берникадәр үсендерү. *Сүзләремне дә ярattылар бугай, һәрхәлдә, бергә барган каләмдәшләрем: «Чыгышың әйбәт булды, молодец!» – дип, үземне үсендереп алдылар.* Р.Миңнуллин. *Ара-тирә җиңүләрегез турында искә төшереп, үзегезне үсендереп алыгыз.* Сөембикә

**Үсендереп бетерү** Бик нык үсендерү. *Без артистларны мактый-мактый үсендереп бетердек, ахрысы.* Мәдәни җомга

**Үсендереп җибәрү** Көтмәгәндә яки бераз үсендерү. *Әле колхоз рәисе: – Харис малае икәнлегеңне күрсәт әле, энем, сәгать кебек келтерәп кенә йөри торган ит үзен, – дип үсендереп тә җибәрде.* Г.Бәйрәмова. *Әлеге уйлары Әкбәровны үсендереп җибәрде.* З.Хөснияр

**Үсендереп йөрү** *к.* **үсендереп тору**. *[Иман дигән әйбер] Җан-рухны дәртләндереп, үсендереп йөри, яшәүгә, киләчәккә өмет бирә.* Г.Гыйльманов

**Үсендереп килү** Күптәннән бирле үсендерү. *«Синең сулышың киң, гәүдәң бар, рәхәтләнеп опера сәхнәсендә чыгыш ясый аласың», – дип үсендереп килде.* Ватаным Татарстан

**Үсендереп кую** Бер мәртәбә үсендерү. *Кайчан аны юктан гына да мактап алдың, үсендереп куйдың?* Г.Гыйльманов. *Китап тотып шәм тирәсендә озаграк утырган чакларымда әбием: – Шәкертҗан агаң кебек укымышлы булырсың, ахрысы, – дип үсендереп куяр иде.* Л.Хәмидуллин

**Үсендереп тору** Даими үсендерү; әле, хәзер үсендерү. *Әле ярый Балдак Даладагы бүтән үсеш аның күңелен дәртләндереп, үсендереп торды.* В.Имамов. *Алайса кем эшләсен бу эшләрне? – Хәзер син әтиең урынына калдың, – дип үсендереп тора әнисе.* Р.Газиз

**ҮСЕНТЕ** *и.* 1) Әле генә шытып чыккан вак үлән яки агач үсемлек. *Тимердәй каты кәүсәле бу мәһабәт агач тирәсендәге кардан арчылган җирдә инде беренче яшел үсентеләр тибеп чыккан.* А.Вергазов

2) Үсемлекнең сабактан, тамырдан яки орлыктан чыккан яшь яралгысы. *Әлеге аланнан әз генә өстәрәк, чыршы, нарат үсентеләре утырту өченме, урманчылар трактор белән сызган киң генә ызан бар.* А.Хәсәнов. *Куе урман үләне арасыннан сукмаксыз җирдән, кычыткannарны, кура җиләге үсентеләрен аралап, бер-бер артлы алар озак бардылар.* Д.Каюмова

3) *махс.* Берәр органның тармакланып киткән өлеше. *Гадәттә, тешсыман үсенте олыларда һәм балаларда төптән яки атлантның алгы җәясе яки аркылы бәйләвеч басымыннан сынарга мөмкин.* Фән һәм тел

**ҮСЕНТЕЛЕК** *и.* 1) Үсентеләр күпләп үскән урын

2) Үсентеләр үстерү өчен махсус урын; питомник

**ҮСЕНҮ** *ф.* 1) Рухланып китү, күңел күтәрелү. *Мин аларның уйнап сөйләгәннәрен бик яхшы аңлыйм, тиле күңел нишләргә белми: үсенә, җилкенә.* Н.Фәттах

2) Масаю, эреләнү, һавалану. *Шулай үсенеп кенә йөргәндә, без сабактан көчкә кайтып егылдык.* Ш.Маннур. *– Исламны әле белмисең син, Глеб Семёныч! – диде Ислам, үсенеп. – Миннән башка ышанычлы кешең дә юк синең монда.* Н.Фәттах

**Үсенә бирү** Бернигә карамый үсенү. *Әйдә, үсенә бирсеннәр, балакайлар.* Ф.Хуҗин

**Үсенә төшү** Бераз үсенү

**Үсенеп китү** Көтмәгәндә үсенү; соңгы вакытта үсенү. *Соңгы вакытта бу кызыкай артыграк үсенеп киткән иде шул.* М.Маликова. *Бала бала инде – Бакый үзе дә үсенеп китте хәтта, бераз гына көйләтә, назландыра башлады.* Г.Гыйльманов

**ҮСЕШ** *и.* 1) Организмның яки аерым органнарның үсү процессы. *Дөрес, Дарвинның беренче үсеш баскычы булып торучы маймылдан ул беразга өстенрәк була алды.* К.Җәмит. *Яшь, җитлекмәгән организм үсеш процессында гына әле, тәмәке тарту аның өчен аеруча куркыныч.* Сабантуй

2) Сан ягыннан арту, күбәю. *Шәһәрләр үсеше*

3) Ныгу, арту күренеше. *Алар озак вакытка салынган инвестицияләрнең эшкуарлык активлыгының үсеш алуы нәтиҗәсендә капланачагына исәп тоталар.* Тәтеш таңнары

4) Сыйфат ягыннан алга китеш; күтәрелеш, яңарыш. *Колхозларның алга таба үсешендә алар киртә түгел, киресенчә, файдалы булулары хакында яза да, сөйли дә башладылар.* В.Нуруллин. *Бүгенге җәмгыятьнең үсешенә, андагы төрле-төрле һәм эреле-ваклы үзгәрешләргә, табигать кануннарыннан тыш, тагын башка көчләр дә тәэсир итә, зур йогынты ясый түгелме соң?..* З.Хөснияр

5) Ниндидер бер юнәлештә кешенең камилләшүе, осталыгы арту, уңай сыйфатлары барлыкка килү күренеше. *Без Галиянең үсешен күрмибез.* М.Җәлил. *С.Рәмиев иҗатының үсеш чоры 1906–1910 елларга туры килә.* М.Хәсәнов. *Бу бик күңелсез, иҗади үсеш өчен бернәрсә дә бирми торган эш канәгатьләндерми иде кызны.* М.Кәбиров

◊ **Үсеш алу** Киңәеп үсү, нык үсү. *Аларда, һәртөрле ирекләр булу сәбәпле, мәдәният искиткеч югары үсеш ала.* Г.Ибраһимов. *Комсомоллар катнашында студентлар төзелеш отрядлары, «Кар десанты», җәмәгать иминлеген саклау буенча комсомол дружиналары, яшьләрнең төрле формалардагы иҗат һәм фәнни активлыгы үсеш алды.* Шәһри Казан

**ҮСЕШЛЕ** *с.* Үсеп бара торган; перспективалы. *Бүгенге көндә дә Татарстан, Федерациянең тотрыклы үсешле субъекты буларак, Россия дәүләтенең ныгуын дәлилли.* Авыл таңнары

**ҮСКӘН** *с.* **1.** Зур булган, җитлеккән; балигъ булган. *Син бит инде хәзер үскән егет, үндүрт яшең тулып килә, кул арасына керә башладың...* Н.Гамбәр

**2. үскәнем** *и. мәгъ. ирк.* Үзеннән кече кешегә (балаларга, яшьләргә) иркәләп, яратып эндәшү сүзе. *Бергә яши башлагач ук, «үскәнем, акыллым» дип кенә торды аңа [кыз].* В.Нуруллин. *Тәм-том пешергән саен, сине искә алабыз, үскәнем.* Р.Кәрами

**ҮСМӘ** *с.* Үсеп утырган үсемлекләрдән торган. *Үсмә читән*

**ҮСМЕР** *и.* **1.** 12 –17 яшьләрдәге бала; яшүсмер. *Ике үсмер, чыклы үләннәрне яра-яра, һауһаулап, ат көтүе куып кайталар.* А.Гыйләҗев. *Аңа татар мәдрәсәләрендә башлангыч белем*

*алган, унбиш яшьтән дә яшь булмаган үсмерләр кабул ителгән.* Л.Хәмидуллин

**2.** *с. мәгъ.* Үсеп килгән, физиологик җитлегү чорындагы. *Ә бит балачак, үсмер чор, яшьлек еллары, гадәттә, кеше хәтеренә матур бизәкләре, мизгелләре белән уелып кала.* Д.Гыйсметдин. --- *урман эшенә ярамаган халык: хатын-кызлар, үсмер яшьләр, олы кешеләр – барысы да хәлләреннән килгәнчә кырларда, фермаларда эшли.* З.Мурсиев

**ҮСМЕРЛЕК** *и.* 1) Үсмерчак, кешенең үсмер булган вакыты. *Үсмерлектән егет чорына кереп җитмәгән, туп кебек тыгыз, беләкләре, күкрәкләрендәге сум итләре түгәрәкләнеп, бүселеп торган егеткәй әле исеменең мәгънәсен үзе дә аңлап җиткерми.* А.Хәлим. *Үсмерлектә үзеңне гел яшь дип санап йөрисең бит ул, бер-ике яшькә генә өлкәннәр дә тормышның икенче офыгында торадыр кебек.* Р.Рахман

2) Үсмерләргә хас сыйфатлар, үсмер билгеләре. *«Шунда!» – дип җаваплады үсмерлеге чыраеннан чыгып бетмәгән тракторчы.* А.Гыйләҗев

**ҮСМЕРЧАК** *и.* Гомернең балалыктан яшьлеккә кадәрге 12–17 яшьләр аралыгындагы вакыты. *Мәхәббәтнең нәрсә икәнлеген мин иртәрәк, ахры, аңладым: Җырым бөреләнгән үсмерчагым, гашыйк булган чыклы таңнарым...* И.Юзеев. *И ул үсмерчакның татлы йокылары!* Г.Бәйрәмова

**ҮСТЕРҮ** *ф.* 1) Үсемлекләрне, хайваннарны карап, махсус рәвештә шартлар тудырып үрчетү. *Сылукайның үзе тәрбияләп үстергән юртак биясен, Ак юрганы корбан чалырга?* А.Гадел. *Тугызынчы дистәне ваклый башласа да, Шәмсенур карчык шактый нык иде әле: хуҗалыктагы бөтен нәрсәгә җитешә, су сибә-сибә бакча җиләге үстерә, кош-кортын тәрбияли, ә дигәнче оекбаш-бияләен бәйләп ташлый.* А.Әхмәтгалиева

2) Баланы тәрбияләп өлгергәнлек яшенә җитүен тәэмин итү. *Җиде бала үстереп бирдем туган илгә.* А.Хәмзин. *[Усман карт] Карчыгы Рәкыя белән алты бала – бер ул, биш кыз тәрбияләп үстерделәр.* А.Хәйретдинова

3) Үсәргә мөмкинлек бирү, кисмичә, кыркымыйча тору. *Ул, башкалар кебек, мыек үстермәде үстерүен, әмма ирен почмакларында ихтыяр көченең билгесе булган тирән сызыклар барлыкка килде.* Г.Әпсәләмов. *Кыланышың әштер-өштер, Егет дигән даның корсын. Акыл булмагач, чәч үстер, Җык җилкәңә төшеп торсын.* Г.Афзал

4) Талант, иҗат һ.б.ш. үсешенә булышу, камилләштерү, осталыкны арттыру. *Талантыңны үстерәсеңме, үтерәсеңме – анысы үзеңнән тора.* Г.Кутуй. *Карл Брюллов рәссамнар башкаласы Римга укырга, профессиональ осталыгын үстерергә килә.* А.Хәсәнов

5) Әдәбият һәм сәнгать әсәрләрендә эчтәлек, фикер һ.б.ны эзлекле рәвештә дәвам итү, тирәнәйтү, катлауландыру, киңәйтү. *Пьесадагы төп фикер тагын да зуррак, автор тагын да тирәнрәк казый, фикерен үстереп, ул логик нәтиҗәгә килә.* А.Әхмәдуллин

6) *күч.* Арттыру, күтәрү (бәя тур.). *Җитештерүчеләр, үз чыгымнарын каплау өчен, товар һәм продукция бәясен үстерә.* Кызыл таң

7) *күч.* Рухландыру, күңелне күтәрү. *Нияз тагын яныма килә, күңелен үстерлек өметле сүзләр көтеп, күзләрен миңа бага.* В.Нуриев. *Мондый хис җәһәннәмдә дә кешенең күзләрен нурландыра, җанын канатландыра, рухи көчен үстерә, акылын чарлый.* Г.Әпсәләмов

8) *күч.* Нәрсәне дә булса югары дәрәҗәгә күтәрү, үсешен тәэмин итү. *Тамашачының зәвыгын үстерә алмаса, театрның киләчәге юк.* А.Тимергалин. *Димәк, авылны зурайтырга, үстерергә кирәк.* З.Мурсиев

9) *күч.* Карьера баскычы, хезмәт урыны һ.б.ш.да югарырак күтәрә бару. *Бүтән чакта сәләтле яшь кадрларны үстерергә, зур эшләр башкарырдай кадрлар тәрбияләргә кирәк дип фәлсәфә сатарга бик яраталар.* В.Нуруллин. *– Менә син, Галимәрдән, бик тырыш кеше. Сүз тыңлаучан. Кыскасы, сине үстерергә вакыт, – диде нәчәлник, елмаеп.* Д.Гыйсметдин

**Үстерә бару** Торган саен үстерү. *Инде сине дәрәҗәңдә дә үстерә барырлар!* Ф.Яхин. *Массакүләм күренешләр вакытында да язучы геройларның индивидуаль сыйфатларын чуалтмый, хикәяләү дәвамында ул сыйфатларны үстерә бара.* Ф.Хатипов

**Үстерә башлау** Үстерергә тотыну. *Әгәр ун көндә асфальт җәймәсәгез, урамда чүгендер, кәбестә үстерә башлыйбыз.* А.Гадел

**Үстерә бирү** Бернигә карамый үстерү. *Сакалга инде ул кадәр бәйләнеп тә булмый, теләгән кеше үстерә бирсен.* С.Рәфыйков

**Үстерә килү** Күптәннән, әлегә кадәр үстерү. *Үзләре иркәләп үстереп килгән вә киләчәктә бик зур өмитләр көткән бу «малкай»лары югалса яки урланып читкә җибәрелсә, анлар өчен мең мәртәбә җиңел булачак иде ---.* Г.Ибраһимов

**Үстерә тору** Даими үстерү; бер-бер артлы үстерү. *Халкыбыз үзе кебек булдыклы, талантлы улларын тудыра, үстерә тора.* С.Рәфыйков. *Шәһәрнекеләр аңа яз көне үк инкубатордан чебешләр алып кайталар, ә Галимә түти аларны үстерә тора, суйдырып биреп җибәрә тора.* Ә.Хәсәнов

**Үстерә төшү** Бераз үстерү; тагын да үстерү. *Киләсе ел өмете белән бәхетле бул, эшкуарлыкны ары табан үстерә төш.* Ә.Баян. *Чернышевскийның нәфасәт өлкәсендәге карашлары бу фәнни тармакны киләчәктә тагын да үстерә төшү өчен зарури кертем булган дип карарга кирәк.* К.Гыйззәтов

**Үстереп бару** Гел үстерү. *Андый сыйфатларны үзендә булдырган хәлдә дә, аларны гомер буе саклап, һаман үстереп бара алу ай-һай җиңел түгелдер!..* Р.Фәйзуллин

**Үстереп бетерү** Барысын да үстерү; күп итеп үстерү. *Тик менә бу сугыш комачау итте аларны үстереп бетерергә.* З.Зәйнуллин. *Нәрсә генә үстереп бетермиләр алар.* Безнең гәҗит

**Үстереп җибәрү** Үсүгә мөмкинлек тудыру, этәргеч бирү. *Кайчандыр яшь-яшь шәкерт булып, ун ел дәвамында остазыннан аерылмыйча йөри-йөри хәзер инде чем кара сакал-мыек үстереп җибәргән тугры мөдире Ирмәшне дә, әлбәттә, үзе белән алды.* В.Имамов. *Ай-яй, Галимулла, бигрәк үзеңә килешеп торган сакал үстереп җибәргәнсең.* Б.Ислам

**Үстереп җиткерү** Кирәк, тиешле кадәр үстерү. *Ул менә шул юл берлә угылыны тәрбия кылып үстереп җиткерде.* Г.Исхакый. *Колхозчының йортында күп дигәндә ун-унбиш баш чебеше була һәм аларны бала-чагасы, карчык-корчыгы туктаусыз ашатып-эчертеп, кош-корт күзеннән саклап тора, ләкин шулай да әлеге ун-унбиш чебешнең барысын да исән-сау килеш үстереп җиткерә алучылар бик сирәк ич...* В.Нуруллин

**Үстереп йөрү** Әле, хәзер үстерү. *Әхмәт, сиңа әйтәм, анаңның ничек эче пошмый ул кадәр чәчеңне үстереп йөрүеңә?* Г.Камал

**Үстереп тору** Даими яки әледән-әле үстерү; әле, хәзер үстерү. *Әле дә Ходай урманнарын ел да яшәртеп, үстереп тора.* Г.Хөсәенов. *Халыкка шул гына кирәк, аны кул чабып үстереп тордылар, ә ул усалланганнан-усалланды.* Ф.Садриев

**Үстереп яту** *сөйл. к.* **үстереп тору**. *Малайларны әниләре ялгыз башы үстереп ята, әтиләре вафат.* Г.Гомәр. *[Кәримҗан:] Тырышып-тырмашып ул үстереп ятам бит, Әнисә ханым!* А.Гыйләҗев

**ҮСҮ** *ф.* 1) Тере организмнарның буе, авырлыгы, микъдары арту, зураю. *Һәрхәлдә, Баллы Елга буйларында казлар көткәндә, безгә тагылып үсте ул.* А.Хәлим. *Чу, ботаклар түгел, аларда үскән алмалар салмак кына тибрәлә икән ләбаса!* А.Мансуров // Берәр орган, әгъзаның күләме арту. *Бүксә үссә үссен икән, буй бәләкәйләнмәсен, буй!* А.Гыйләҗев

2) Олылану; җитлегү. *Әле мәнә үскәч кем булыр?!* А.Хәсәнов. *Ана карынындагы су эчендә яралганда, безгә шул су да җитә иде, ләкин без үстек, буй җиттек, хәзер инде елга сулары да җитмәс төсле.* А.Нәҗми

3) Берәр кайда балалык елларын үткәрү. *Гомерен диңгезгә багышласа да, авылда үскән егет, Украинаның Харьков өлкәсендә туган.* А.Хәсәнов. *Беләсеңдер инде, мин бит детдомда үстем.* А.Әхмәтгалиева

4) Берәр җирдә, урында таралу, булу (үсемлекләр тур.). *Татарстанда каяу яфраклы абага һәм ана абага дигән төрләре үсә.* А.Тимергалин. *Биек тауның башларында Тезелеп үсә әнисләр.* А.Хәлим

5) Билгеле бер озынлыкка җитү (чәч, сакал, мыек тур.). *Миңа сакал үсә иде, хәзер бетте, җаннарым сихәтләнеп, тынычланып калды.* М.Мәһдиев. *Ярар, чәч үсә ул, баш исән булсын.* Г.Бәйрәмова

6) Сан һәм күләм, активлык ягыннан арту. *Ягъни драматургларыбызның иҗат активлыгы үсте.* А.Әхмәдуллин. *Очкын биргән кемдер, Ут кабынган, Ут үрләгән күккә – Җир шарына капкан фән уты. Зур сарайлар үскән, Зур биналар – Бу тарихның нәкъ шул вакыты.* Б.Ибраһим. *Хәсәнҗан сәетнең гаскәре яңа кешеләр белән тулылана, үсә, мең кешедән артып китә.* В.Гали // Арту, күтәрелү (бәя, процент, налог һ.б.ш. тур.). *Почта чыгымнарының чүпрәдәй күпереп үсүе аркасында, Татарстанда чыга торган гәҗит-журналга да язылмыйлар хәзер.* Б.Рәхимова

7) *күч.* Җәмгыятьтә берәр күренеш таралу, җәелү. *Чувашларның борынгы бабаларында феодаль җитештерү мөнәсәбәтләре Идел буе болгарлары йогынтысында безнең эраның икенче меңьеллыгыннан башлап үсә һәм саклана.* Б.Хәмидуллин

8) *күч.* Камилләшү; яхшыру, ныгу. *«Бәхетле солдат» тормышын, халыклар дуслыгын данлаудан башланган иҗат үсә, тирәнәя бара.* Т.Галиуллин. --- *вакытында җырчыга бәя бирә белгәндә генә, талант үсә, ныгый ала, чөнки җырчыга зур югарылыкта җырлау өчен бирелгән вакыт бик аз ул.* Г.Ибушев

9) Рухи үсеш кичерү, җитлегү, өлгерү. *Балаларның эчке дөньясы кечкенәләр якын өмете белән, изге тойгылары, яхшы уйлары белән нурланып үссен.* Г.Бәширов

10) *күч.* Берәр төр сыйфатлар көчәю, үсеш алу. *Ул чорда демократик карашлар үсте, халыкның социаль активлыгы көчәйде.* Мәдәни җомга

11) *күч.* Дәрәҗә, дан арту, абруй күтәрелү. *Сүз дә юк, аның абруе күзгә күренеп үсте.* А.Хәлим. *Халык белән шәхес даны үсә, Шәхес белән халык танала!* Э.Шәрифуллина

12) *күч.* Үсенү, рухлану. *Тормыш юлында, гомерем соңында Яшьлек дәфтәрен актарсаң иде... Күңелең үсәр, Исеңә төшәр: Онытма мине! Онытмам сине!* И.Юзеев. *Суык таштан кояш ясый алмасак, без үткәндә үлән шытып калмаса, йөрәктәге йөрәкләргә күчмәсә, безнең сүздән кеше рухы үсмәсә, бәхет теләп текәлмәсә кешеләр, яшәде дип, безнең хакта кем сөйләр!* К.Сибгатуллин

13) *күч.* Эш, карьера һ.б.ш. өлкәләрдә алга бару, уңышларга ирешү. *Ә хатын-кыз исә тагын да эшлеклерәк булырга тырыша: карьерада үсү өчен, чиксез күп көчен бирә ул, бар җирдә тәртип булсын, балалар караулы, ир тыныч, канәгать булсын өчен, тиресеннән чыгардай булып тырыша.* Өмет. *Ел азагында яңа урынга күчү яки эштә үсү җае туар.* Маяк

14) *күч.* Ачыграк төс алу, билгелерәк булып китү. *Шыгырдавык баскычтан печәнлеккә менгәндә, шик үсте, баш миенә, бөтен тәнгә җәелде.* Ф.Шәфигуллин. *Үз-үзләрен, теләк-омтылышларын, борчу-мәшәкать сәбәпләрен аңлый барган саен, үкенү хисе дә үсә.* Идел

15) *күч.* Яңару, яхшыга үзгәрү, үсештә яңа баскычка күчү. *Ягъни Алла тарафыннан яратылган реаль чынбарлык алга таба үз агымы белән һәм кануннары буенча тәрәккый итә, үсә, адәм баласы өчен беренчел, танып белүгә мохтаҗ өлкә булып кала бирә.* А.Әхмәдуллин

**Үсә бару** Торган саен үсү. *Аңар да карамыйча, шаулап, бөтерелеп аккан кечкенә елгачык һаман зурая бара, үсә бара.* А.Алиш. *Үзенеке булганы агач кәүсәсе сыман югарыга үсә барырга, ә инде читтән килгәннәре шул агачның ботак-яфраклары кебек аны баетырга, тулыландырырга тиеш.* А.Вергазов

**Үсә башлау** Үсәргә тотыну. *Кыярлар, кабаклар да яфрак чыгарып үсә башладылар.* А.Алиш. *Озакламый аның чәчәге тишелеп чыкты, күзгә күренеп үсә башлады.* Г.Сабитов

**Үсә бирү** Бернигә карамый үсү. *Ис китми: янындагы айгыр-тулпарга Җикеренеп, батырланып кыланса да, Ак төя, ак аргамакларыннан да, Маңлаен терәп торган тавыннан да Ул көчле барыннан да, барыннан да, Сокланып зур кояшка яшь чактан ук, Шулай ул үсә бирә киң далада.* Н.Думави. --- *баланың тамагы тәмле аш татымады, өстенә-башына хәерче кебек сәләмә киенде, күлмәге ямалмады, юылмады – шулай үгилекнең каты кулында чыбыркыланып, җәй көне ялангач тәнгә кычыткканланып үсә бирде.* Г.Ибраһимов

**Үсә килү** Әлегә кадәр үсү. *Моннан өч йөз еллар элекке бер вакытның, шул эчендә яшәгән бер халыкның ихтыяҗыннан туган бер дин инде унөч гасыр буенча туктаусыз үзгәрә, үсә килгән бер хәятка ярамый, тар була.* Г.Ибраһимов. *Ә матурлык туган Кеше белән, Кеше белән бергә үсә килгән.* Р.Сәйфетдинов

**Үсә тору** Һәрдаим үсү. *Фронтта югалган тузгак яллы айгырлар, бүрек кадәр бәкәлле бияләр урынына киң Ашыт, мул сулы Илләт буйларында яңалары үсә торды.* А.Хәсәнов

**Үсә төшү** Бераз үсү; тагын да үсү. *Микәй атлы бу бәти бүре авызына эләгә язып та кала, үсә төшкәч, көндәшләре – башка тәкәләр белән мәрхәмәтсез бәрелешләрне дә уздыра.* Р.Мөхәммәдиев. *Үсә төшкәч, дөнья таный башлагач, ул якларга бер кайтканыем.* А.Хәсәнов

**Үсеп алу** Бераз үсү. *Бераз үсеп алгач, 1911 елдан башлап Глүшермә, Бондюг, Иж, Воткинск заводларына эшкә йөри башладым.* Т.Гыйззәт

**Үсеп бару** Акрынлап үсү, үсүгә йөз тоту. *Хәзер бөтен нәрсә дәррәү кузгалып, күтәрелеп, үсеп бара: арышлар сабакка сузыла башлаган, бодайлар куе булып, кучкыл яшел булып, егетләр мыегыдай, сызылып кына чыгып килә ---.* Ә.Еники. *Чөнки Нургалиев өметле, үсеп бара торган кеше иде.* А.Гыйләҗев

**Үсеп бетү** Бик нык үсү; тәмам җитлегү. *Мирвәли заманында туып кына килгән яңа буынның үз бала-чагалары үсеп беткән...* А.Гыйләҗев. *Борын астына ирләрнеке сыман мыек үсеп беткән.* В.Имамов

**Үсеп җитү** Тиешле дәрәҗәдә үсү. *--- алар киләчәктә, мин үсеп җиткәч, дөньяның иң атаклы музейларында очратачак сирәк сәнгать мирасы – борынгы Мисыр, Юнан, Вавилон, Бөек Болгар, Бакчасарай мәдәни катламнарында сакланып кала алган ике яктан да токкалы алтын кәүшән – чүкеп ясалган алтын амфораны хәтерләтәләр иде.* А.Хәлим. *Өч ел эчендә Полкан үзе дә бер дигән маэмай егете булып үсеп җитте.* А.Хәсәнов

**Үсеп килү** Акрынлап үсү; күзгә күренеп үсү. *Һәрбер эшне җитез эшли торган Корыч кебек ике улым бар, Ике кулым кебек үсеп килгән Булышчым бар, ике улым бар.* А.Алиш. *Алма кебек малайларың тупылдап үсеп килә.* А.Вергазов

**Үсеп китү** Кинәт яки бераз үсү. *Безнең бабайлар өянке утыртканнар да, тиз тамырланып үсеп китсен өчен, башына черемә сөртеп, чүпрәк белән бәйләп куйганнар, ә кәүсәсен, кәҗә кимермәсен өчен, каты юкә кабыгы белән ураганнар.* А.Вергазов. *Күңел үсеп китте бит әле, егетләр, югыйсә мин бу тормышта өмет-ышанычны бөтенләй югалтып бара идем инде.* В.Нуриев

**Үсеп кую** Тиз арада, кинәт үсү. *Алмагачны утыртуга, икенче көн иртәнгә ул үсеп куйсын, өйләгә чәчкә атсын, кичкә алмасы пешсен дә авызга төшсен.* М.Маликова. *Мин кайтканчы ничек матур булып үсеп куйган безнең кияү ---.* Г.Галиева

**Үсеп тору** Даими яки әледән-әле үсү; әле, хәзер үсү. *Кызыл, зәңгәр, яшел карандашлар белән үсеп торган алмагач күк итеп ясарым.* Г.Бәширов. *Кайчандыр кабар, гөләп куаклары, карга күзе һәм тайтояклар үсеп торган, ә хәзер сукаланган җир кебек актарылып беткән, үлекләр, җимерек кораллар, шартлатылган, яндырылган танклар белән капланган бу үзәнлек Мурманск – Печенга шоссесының ачкычына әверелде.* Г.Әпсәләмов

**Үсеп чыгу** Бик тиз үсү. *Халык исән булса, яңа калалар да үсеп чыгарлар.* А.Гадел

**Үсеп яту** *сөйл. к.* **үсеп тору**. *Гаилә ишле: җизнәсе белән Әминә апасының өч баласы тәгәрәп үсеп ята.* Р.Низами. *Герман илендә баласы үсеп ята, нәсел ядкәре.* Ф.Яхин

**ҮТ** *и.* 1) Ашаган азыкны үзләштерерлек итеп таркату өчен бавырдан эчәкләргә бүлеп чыгарыла торган яшькелт төстәге ачы сыеклык. ---*Үсемлек составындагы флавоноидлар үт куыгына үт сыекчасы бүленеп чыгуын арттыралар.* Агулы үсемлекләр

2) *күч.* Ачу, зәһәр. *Чөнки тормыш гаделсезлегеннән, иренең эчүеннән Сәрдәнең җанына ачы үт җыелып тора.* Ф.Садриев

◊ **Үте кайнау** Ачуланып, зәһәр чәчеп йөрү. *Мәскәү белән Суздаль кенәзләрен Рязаньдагы Олег та һич өнәми, һәр икесенә үте кайнап тора.* В.Имамов. **Үтен сыту** Ачуны чыгару. --- *Ходайбирдинның һични булмаган кебек әллә кайчангы торбалар турында мыскыл иткән, үртәгән сыман сорап куюы әйтерсең Сәхабның үтен сытты, җен ачуларын чыгарды.* М.Хәбибуллин. *Ни тыелырга тырышса да, полковникның үте сытылды. – Сөйгәнем генә түгел, хатыным ул минем! – дип ярып салды Вилен үзе дә көтмәгәндә.* М.Маликова. **Үт капчыгына таш булып утыру** Бик авыр тәэсир итү. *Сталинград вакыйгасы фашистларның үт капчыгына таш булып утырды.* Г.Галиев. **Үткә тию** Бик нык ачуны китерү. *Әмма тынычланып та булмый, иң нык үткә тигәне – Дәүләтьяров хакында Югары Совет сессиясе булачак көн җиткәнче Алемасов ләм-мим бер сүз әйтми йөрде.* Ф.Сафин. *Турылыгы да кайвакыт үткә тиярлек.* Сөембикә. **Үтне сытарлык** Бик ачы

**ҮТӘ** *рәв.* 1) Берәр нәрсәнең бөтен калынлыгы аша үтеп чыгып; аша, үтәли. *Агач нәселе җир үтә кергә, адәм нәселе ил үтә кергә.* Мәкаль. *Егетнең күңел сафлыгы чишмә суыдай үтә күренеп тора иде.* Ш.Маннур

2) Бик, чиктән ашкан, гадәттән тыш, гаять, иң. *Шушы Сидоров, ротага килүе белән, үзенең үтә формалист, шунлыктан аеруча дорфа икәнлеген күрсәтеп өлгерде.* Ә.Еники. *Коридорлар киң, түшәмнәре шундый биек, тәрәзәләр үтә дә олы, якты.* Ф.Садриев

3) Иң реакцион, ультра. --- *алар үтә уң һәм үтә сул радикаллар дип билгеләнде ---.* Л.Харрасова

◊ **Үтә киткән** *к.* **үтә чыккан**. *Сәгыйть Рәмиев... Үтә киткән нечкә күңелле, хисчән шәхес, шагыйрь.* М.Гайнетдин. **Үтә күрену** Бик ябык булу. **Үтә кызыл** Алдынгы фикерле булып кыланган. **Үтә чыккан** Бик, артык, чиктән ашкан. *Күрше Мөршидә апаның Мөхәммәт исемле үтә чыккан шук малаен хәтерлисеңдер.* А.Гыйләҗев. *Аның икенче төп сыйфаты – үтә чыккан саранлык.* Т.Галиуллин

**ҮТӘДӘ́Н-ҮТӘ** *рәв.* Нәрсәнең дә булса бөтен калынлыгы аша үтеп, бер яктан икенче якка; ашадан-аша. *Ул чагында детальне үтәдән-үтә күреп була.* Г.Әпсәләмов. *Тик инде чишмәгә төшкәндәге тынычлыгы качкан, кемнеңдер карашы аны эзәрлекли, үтәдән-үтә бораулый һәм әледән-әле башын күтәреп карарга мәҗбүр итә.* Н.Әхмәдиев

2) Ачыктан-ачык. *Күлнең суы гаҗәп чиста, үтәдән-үтә күренә иде.* Г.Әпсәләмов. *Өсте зәңгәрсу, төбенә кадәр үтәдән-үтә күренә, ә төбе караңгыланып тора.* Ә.Еники. *Һава саф, үтәдән-үтә күренә.* И.Салахов

**ҮТӘКҮРЕНМӘ́ЛЕ** *с.* 1) Артындагы нәрсәне томаламый торган, ашасыннан. *Эреләнә төшкән яңгыр тамчылары күлдәвеккә төшкәндә, су өстендә үтәкүренмәле куыклар хасил була ---.* А.Вергазов. *Ап-ак, үтәкүренмәле каурый болытлар тезмәсен кем шулай зифа рәтләргә тезә ---.* А.Хәлим

2) Юка, тишекле-тишекле булу сәбәпле, яктылыкны үткәрә торган. *Үтәкүренмәле, итәге ханбикәләрнекедәй кабартып тегелгән алсу күлмәге аның төз гәүдәсенә үлчәп тегелгән ---.* А.Нәҗми

3) Кирәгеннән, тиешеннән күпкә юкарак. *Иләк кебек үтәкүренмәле соры шинель. Үтәкүренмәле телем бирү*

4) *күч.* Катлаулы булмаган; ачык күренә торган. *Турысын әйткәндә, әдәби тәрҗемә ул әле борынгы текстны, архаиклыктан тәмам арындырып, бүгенге үтәкүренмәле, бер калыптан суккан җөмләләр белән алыштыру дигән сүз түгел.* А.Тимергалин. *[Фәрдәнә:] Ул яктан минем бәхетләр хәттин ашкан – үтәкүренмәле!* Ә.Гаффар

5) *күч.* Бик ябык. *Кулына алгач, әбекәй үз гөләнә озак кына карап торды, аннары неп-нечкә, үтәкүренмәле бармаклары белән аның яфракларын, чәчәкләрен сыйпап алды ----.* Г.Гыйльманов

6) *күч.* Ачык аңлашыла торган. *Берсе – халыкның сөйләм теле нигезендә калыплашкан, мифологик сюжет-мотивларга, лирик җырларга таянып, балалар өчен язылган әсәрләренә хас үтәкүренмәле реалистик өслүб.* Т.Галиуллин. *Бу идеяне социализм төзү, халыклар һәм милләтләр тигезлеге дигән үтәкүренмәле идея алыштырды.* Ә.Закирҗанов

**ҮТӘКҮРЕНМӘЛЕЛЕК** *и.* Үтәкүренмәле булу сыйфаты. *Йомгаклап әйткәндә, татар драматургиясен басып алган үтәкүренмәлелек фонында Зөлфәт Хәким драматургиясендәге катлаулылык перспективалырак.* А.Әхмәдуллин

**ҮТӘЛЕШ** *и.* 1) Нинди дә булса эшне үтәү, шуның үтәлү микъдары, дәрәҗәсе, нәтиҗәсе. *Җаваплы операцияләрнең үтәлешен тикшереп бармасаң, син нинди җитәкче.* Г.Әпсәләмов. *План үтәлеше, рентабельлек, үзкыйммәт, продукция җитештерү – барысы да ал да гөл.* Р.Мирхәйдәров

2) Үтәү рәвеше, сыйфаты. *Бер атнадан соң бүлмәләрне карап йөргәндә, санитария кагыйдәләренең үтәлешен тикшергәндә, шифоньер артыннан аның пиджагы килеп чыкты...* Р.Кәрами. *Законнар чыгара, тик аларның үтәлешен тәэмин итә алмый.* Н.Шәрифуллин

**ҮТӘЛЕШЛЕ** *с.* Үтәргә мөмкин булган; һичшиксез үтәлергә тиешле. *Мәктәпнең дежурные Рауза апа директор сүзен үтәлешле закон урынына кабул итә.* К.Кәримов

**ҮТӘЛЕШСЕЗ** *с.* 1) Үтәлми калган. *Үтәлешсез эш*

2) Үтәп булмый торган. *Үтәлешсез планнар*

**ҮТӘЛИ** *рәв.* **1.** 1) *к.* **үтәдән-үтә**. *Үтәли күренеп торган буш вагоннардан сыңар җан иясе дә төшмәде.* А.Тимергалин. *Әхмәтзәкинең кырыкны тутырган буйдак улы Такташ, сүзенә дәлил итеп, аркасы аша кереп, түшеннән, янәсе, үтәли чыккан яра эзе бар икән, шуны тәненнән табып күрсәтә ---.* Ф.Яхин

2) Аша, билгеле бер вакыттан соң. *Бөек халык монда башын салган, Сагыш кайта еллар үтәли. Кабер өсләренә өй торгызып, Тыныч йоклап була микәнни?* И.Гыйләҗев. *Агыйделдә боз китә. Уфа күрә, ул Тукайны күрә, Күрә аны еллар үтәли.* Р.Вәлиев

**2.** *бәйл. функ.* 1) Буенча, дәвамында. *Карап торсаң күз иярми кулларына. Ат савалар яз үтәли, җәй үтәли. Атка менеп чабышсалар, җил җитәлми.* В.Ильясов

2) Ярдәмендә. *Бозлы эчемлекне салам үтәли суыра-суыра, Зоя моңа каршы: «Рәхмәт. Мин риза», – диде.* А.Толстой

**3.** *с. мәгъ.* Капма-каршы ачыклыкларның берсеннән икенчесенә үтеп йөри торган; бер нәрсә аркылы үтә торган, аша чыккан. *Кара моны, үтәли җилләр сызгыра.* Г.Камал. *Ике яктан да ачык тәрәзәләрдән үтәли җил йөри.* Ф.Бәйрәмова. *Үтәли юл. Үтәли яра*

**ҮТӘҮ** *ф.* 1) Эшне эшләү, башкару, гамәлгә ашыру. *Әйе, зур эш. Ләкин аны үтәү өчен, мин хәзерге минуттан ук Берлиннан китәргә тиешмен.* А.Алиш. *Приказ үтәргә ашык.* А.Хәсәнов

2) Билгеле функция башкару; берәр максатта куллану. *Бездә элекке мәдрәсәләрдә парта хезмәтен үтәгән озынча тәбәнәк өстәлне күрси дигәннәр.* А.Тимергалин

3) Билгеле таләпләргә туры китереп эшләү, җиренә җиткерү. *Алга куелган бурычны үтәдек.* А.Алиш. *– Исәнме, кызларым! – диде карчык, икесенә дә серле елмаеп, – мин кушканнарны үтәдегезме?* А.Нәҗми

4) Билгеләнгән кадәр күләмдә эшләү, тутыру. *Төзүчеләр көнлек нормаларын үтәделәр кебек.* А.Тимергалин. *Өлкән оператор – җитәкче ул, Җаваплы башкалар өчен дә. План үтәп, сыйфатлы эшләргә Белемен дә бирә, көчен дә.* Г.Сафин

5) Канәгатьләндерү, уңай хәл итү. *Бары тик шуннан соң гына Чалдаев, аның соңгы васыятен үтәп, хатны Әбүзәр абзыйга тапшырган.* Г.Әпсәләмов. *Яшьләрнең үтенечен үтәп, аларның саф мәхәббәтен һәм изге ниятләрен хуплап, ул Нәфисәнең әти-әнисе янына килә ---.* А.Әхмәдуллин. *Әгәр таләбеңне үтәмәсәм?* А.Гадел

**Үтәп ату** *сөйл.* Тиз арада яки җиңел генә үтәү

**Үтәп бару** Һәммәсен үтәү; эзлексез үтәү. *Үз нурмаңны үтәп бара алсаң да...* А.Гыйләҗев. *Мөнәҗҗим хәзрәт әйткән эшләрне вакытында үтәп бардым, ул хәтта мине үзенең урынбасары итәргә дә җыена иде шикелле.* А.Тимергалин

**Үтәп бетерү** Тулысынча үтәү. *Ә күн заводы комсомоллары икенче квартал планын вакытыннан элек – 15 майга үтәп бетермәкчеләр.* А.Алиш. *Башка колхозлар инде икмәк планнарын үтәп бетереп килә, хәтта үтәгәннәре дә бар, ә «Кызыл үрнәк»нең планы үтәлергә бик күп кирәк иде әле.* В.Нуруллин

**Үтәп җиткерү** Тиешле дәрәҗәдә үтәү. *Бу бүлек, безнеңчә, «Көтегез!» шигыреннән соң үз вазифасын үтәп җиткерә алмый.* М.Шабаев. *Аңлау гына җитми, әлеге җаваплы эшне ахырынача үтәп җиткерергә кирәк.* С.Поварисов

**Үтәп йөрү** Әле, хәзер үтәү. *Коммунист буларак, горком кушканны үтәп йөрим бит.* А.Хәсәнов. *«Бик еш сәяхәт итү һәм кәсеп итү битлеге астында берәр яшерен эш тапшырылып, шуны үтәп йөрмәдеме икән, Алла белсен!» – дип яза мөхтәрәм галимебез.* А.Тимергалин

**Үтәп калу** Үтәргә өлгерү. *Әйтеп кенә кушылган эшне соңгарак калдырып үтәп була. Яртысын гына үтәп калырга була.* В.Нуруллин

**Үтәп килү** Әлегә кадәр эзлекле рәвештә үтәү. *Буңа кадәр булдыра алган кадәре Баку мөселманнары шул вазифаны азлап-азлап үтәп киләләр иде.* Г.Исхакый. *Председатель вазифасын вакытлыча партоешма секретаре үтәп килә, ләкин, башка яктан уңган кеше булса да, бу эшкә аның сәләте дә чамалы, теләге бөтенләй дә юк.* В.Нуруллин

**Үтәп кую** Тиз генә үтәү; алдан үтәү. *Шулай итеп, алар бишьеллыкны дүрт елда үтәп куярга җыеналар.* Б.Камалов. *Аны тыңлаганда, Солтанъяр, эштән аз гына бушау белән, бу изге бурычны үтәп куярмын, дип уйлаган иде.* З.Мурсиев

**Үтәп тору** Даими, һәрвакыт үтәү; әле, хәзер үтәү. *Болар да, шулар белән бергә Әмир үзе дә өстәгеләр кушканны «тагын ни боерасыз?» дип карышусызнисез үтәп торучы гади солдатлар гына бит.* В.Имамов. *Алай булса да, бабалары күрсәтмәсен йөгереп үтәп торган оныклар якын булып тоелды Илнурга һәм... үзе дә сизмәстән, чишмәне чистартуга алынган яшьтәшләренә кушылып китте ул.* А.Хәйретдинова

**Үтәп чыгу** Баштан ахыргача үтәү. *Бөтен көч шушы эшне үтәп чыгарга юнәлдерелде.* Г.Әпсәләмов. *Ничек кенә булса да, иртәгәдән дә калмыйча, без менә шушы бурычны үтәп чыгарга тиешбез, иптәшләр!* В.Нуруллин

**Үтәп яту** *сөйл. к.* **үтәп тору**. *Әле дә булса, көн саен диярлек сыйрат күпере кичеп, үзенең ил каршындагы вазифасын үтәп яткан көнә.* Х.Камалов *Үзгәртеп кору өчен, уй-фикер, зиһенфәһем, белем һәм теләк кирәк, ә алар өстән төшкән фәрманны үтәп ятарга гына күнеккән, яңача яшәгәндә исә әзер рецептлар булмый.* Р.Мирхәйдәров

**Үти бару** Һәммәсен, булган берен бер-бер артлы үтәү. *Шулай да Кадыйр*

*крәстиәннәргә биргән сүзендә нык торды, соңга калып булса да, үз вәгъдәсен җиренә җиткереп үти барды.* М.Галәү. *Хатын сөйли торды, кыз кушылган эшләрне үти барды.* К.Тимбикова

**Үти башлау** Үтәргә керешү. *Үземә тиешле вазифаларны үти башларга рөхсәт итегез!* А.Хәсәнов. *Шул рәвешле, гарәпчә текст кечерәйгән, әһәмиятен җуя төшкән һәм үзенә бертөрле бизәк хезмәтен генә үти башлаган диярга мөмкин.* А.Тимергалин

**Үти бирү** Бернигә карамый үтәү. *Мескен солдат, гәрчә приказның дөрес түгеллеген аңласа да, аны [приказны] үти бирә.* С.Поварисов. *Ә табигать синең чамаң-хәлең бармы дип сорап тормый, үз тәртибен үти бирә.* М.Маликова

**Үти тору** Әлегә үтәү; бер-бер артлы үтәү. *ФЗӨгә түгел, фронтка китәчәк ул, ичмаса бер теләген үти торыр.* З.Мурсиев

**ҮТЕЛҮ** *ф. з.-сыз* Үтәргә туры килү. *Ничә чакрым үтелде икән?* А.Гыйләҗев

**ҮТЕМ** *и.* 1) Юлны җайлы гына үтү өчен барлыкка килгән ачыклык. *Аның сулары шунда ук ике якка аерылып, уртада коры үтем барлыкка килә.* Х.Мәхмүтов

2) *икът.* Товарның сатылучанлыгы. *Товарның үтеме кимү*

**ҮТЕМЛЕ** *с.* **1.** 1) Еш сорала, тиз сатыла торган. *Товарлары үтемле товарлар икән.* Т.Гыйззәт. *Совет сәгатенең биредә үтемле мал икәнен белгән, күрәсең.* З.Мәхмүди

2) Иң күп кулланыла торган. *Җәй – чабатаның иң үтемле чагы.* В.Нуруллин

3) Тәэсирле, нәтиҗәле, игътибарга лаек. *Бөтен халыкны авызына каратырлык иң дөрес, иң үтемле сүзләрне каян табып бетергән?* Г.Бәширов. *Халыкка барып җитү, тәэсир итү ягыннан җыр – иң үтемле жанр.* Р.Вәлиев

**2.** *хәб. функ.* Игътибарга алына, колак салына торган (сүз һ.б. тур.). *Ул анда Рәсәй Дәүләт думасында эшли, һәр мәсьәләдә ил эчендә сүзе үтемле.* Ф.Яхин

**ҮТЕМСЕЗ** *с.* 1) Үтми, сатылмый яисә авыр сатыла торган. *--- тик бәяләр генә ике төрле: затлырак, үтемлерәк әйберләрне коммерческий бәя белән, ә үтемсезрәк нәрсәләрне дәүләт бәясе белән саталар...* Ә.Еники

2) Тәэсир көче булмаган, көтелгән нәтиҗәне бирми торган. *Шушындый каршылыклар бердәмлеген ачуга нигезләнгән сурәтле фикерләү рәвеше шагыйрьгә балалар поэзиясенең яңа шигърият чирәмнәрен күтәрергә, үтемсез коры вәгазьдән һәм образсыз информациядән котылырга ярдәм итә.* Казан утлары

**ҮТЕНЕЧ** *и.* 1) Кемнән дә булса берәр теләкне канәгатьләндерүне сорау яки әйтү. *Гармонь фабрикасында мастер булып эшләвемне кунаклар аңлау белән, миңа үтенеч белдерделәр.* А.Расих. *Сезгә бердәнбер үтенечем шул: бер-берегезне ихтирам итеп, аңлашып, миннән соң да, зинһар, тату яши күрегез.* А.Хәсәнов

2) Нәрсә дә булса сорап язылган гариза. *Ул заявкалар, үтенечләр, планнар белән беренче урынбасарын җибәрергә ниятләп, үзе «әллә нигә сырхаулап торам» дип, Иван Ивановичны шомартырга маташканда, шәһәр башлыгы мәсьәләне кабыргасы белән куйды ---.* А.Гыйләҗев. *Шиһабетдин Мәрҗани һәм Хөсәен Фәезхановлар шәһәрләрдә дини һәм фәнни мәдрәсәләр ачу хакында хөкүмәткә үтенечләр язалар.* А.Тимергалин

**ҮТЕНЕЧЛЕ** *с.* 1) Эчтәлегендә үтенеч булган, үтенеп язылган. *Бу тарафтан хаким милләт, милләтчелеген мәйданга кую өчен, фәрманнар, әмерләр чыгара, ә икенче тарафтан (мәхкүмә милләтләрдән) моңа каршы торырга үтенечле гаризалар бара.* С.Максуди. *Белә торып кузгалды, белә торып түрә сараен тирәләде, белә торып куштаннарына ялынды, кучтәнәч-бүләк ташытты, үтенечле хатлар яздыртты.* Д.Булатова

2) Үтенеч, гозер белән килгән. *Үтенечле кеше моннан башын иеп борылып китми.* Ф.Бәйрәмова

3) *к.* **үтенүле**. *Чираттагы ай тотылу кайчан булырга мөмкин, хәзрәт, минем бик беләсем килә, дип, Гәүһәршад көтепханәчегә үтенечле караш ташлады.* М.Әмирханов. *– Рәфис, бер биш сум акча кирәк иде, биреп тора алмассыңмы? – дидем үтенечле тавыш белән.* Б.Ислам

**ҮТЕНҮ** *ф.* 1) Кемгә дә булса берәр эш башкаруын сорап мөрәҗәгать итү. *Әгәр дә [тәрбияле баланың] үзенең көче җитмәслек эшләр булса, ул вакытта зурлардан үтенер...* Р.Фәхретдин. *Нишләгән бу телевизор? Күрсәтми, калган телдән. Бик үтенгәч, төзәтергә Бер абый – оста килгән.* И.Юзеев

2) Түбәнчелек белән мөрәҗәгать итү, ялварып ялыну. *Нигәдер, җилләр, ышанам сезгә, Ярдәм итәрсез төсле безгә. Үтенеп сорыйм минем исемнән Аны табып иркәләргә.* Җыр

3) Кемгәдер берәр нәрсә эшләргә тәкъдим итү. *Я, кадерле кунак, рәхим итеп табынга борылып утыруыгызны үтенәм.* А.Алиш. *Мине бүлдермичә генә тыңлавыгызны үтенәм.* А.Нәҗми

4) *сир.* Теләнү, хәер эстәү. *Әйтерләр: кемнәр хәер-садака иясе түгел һәм монда мохтаҗлыклары юк, ягъни Хак Тәгалә аларны бер сынык икмәктән мәхрүм итмәгән икән, аларга исә хәер үтенеп мәйданга килү, мәчет каршына басу мактаулы эшләрдән күренмәс.* Ф.Яхин

**Үтенә башлау** Үтенергә тотыну. *Шуңа күрә крәстиәннәр Әдигәевтән бәяне киметүне үтенә башладылар.* М.Галәү. *Беркөнне, бутала-бутала, Гөлшәһидәдән гафу үтенә башлады.* Г.Әпсәләмов

**Үтенә бирү** Һаман үтенү. *Һаман әле аны инсафка утыртырга теләп, бичәсе үтенә бирә: – Җитәр инде! Утны сүндер дә ят! – ди.* Ә.Бикчәнтәев

**Үтенә тору** Бертуктаусыз үтенү; әлегә кадәр үтенү. *Ул бертуктаусыз: – Владимир Николаевич, зинһар өчен килә күрегез, – дип үтенә торды.* Казан утлары

**Үтенеп йөрү** Озак вакытлар үтенү. *Хуҗа өч көн буе, акчамны алыгыз инде, дигәндәй, үтенеп йөргән булып чыга.* Кызыл таң

**Үтенеп кую** Алдан яки көтмәгәндә үтенү. *Болай булганда безнең Оренбург имамнары Оренбург губернаторларының да губернатор булып калуын депутатларымызга хат язып үтенеп куйсыннар ---.* Г.Исхакый. *Алдан әйтеп, үтенеп куям: укучылар белән укытучыларча булырга кирәк...* Б.Камалов

**Үтенеп тору** Даими, әледән-әле үтенү; әле, хәзер үтенү. *Ул Мөнирәдән дә үзе турында әтисенә бернәрсә дә язмавын хат саен үтенеп торды.* Г.Әпсәләмов. *Мәрхәмәтле зыян күрүче дә яшь малайны харап итмәскә иде дип үтенеп тора ---.* Безнең гәҗит

**ҮТЕНҮЛЕ** *с.* 1) Түбәнчелек белән әйтелгән. *Әнисенең: «Тукта, балам, китмә! Кичер мине, балакаем!», – дигән үтенүле сүзләре дә аны туктатып кала алмады.* Л.Ибраһим-Вәлиди

2) Үтенү сизелеп торган, үтенүне чагылдырган. *Әтиемнең үтенүле күз карашын әниемнең арыганлык, гаҗизлек һәм шул ук вакытта ниндидер ныклык тулы кискен тавышы телеп үтә ---.* А.Әхмәтгалиева

**ҮТЕНҮЧЕ** *и.* Үтенеч белән мөрәҗәгать итүче

**ҮТЕП** *рәв.* **1.** Берәүдән алданрак, тыйнаксызлык күрсәтеп. *Синең ирең*

*кая? Аңардан үтеп сүз сөйләргә ничек оялмыйсың, битсез!* Г.Ибраһимов

**2.** *бәйл. функ.* Кала, башка, тыш. *Җепнең очы волбашкармада эшләүче бер егеткә барып тоташты. Аңардан үтеп «Трактор» исемендәге зур товар-машина ширкәтенең секретаре да кап-ты.* Г.Ибраһимов

◊ **Үтеп барышлый** 1) Барганда, хәрәкәт уңаеннан. *– Һәрхәлдә, коридордан үтеп барышлый, мин сезнең тавышны ишетеп кердем.* В.Нуруллин. *– Чү, Ибраһим, бу синме? – кемдер үтеп барышлый пышылдап кына эндәште.* И.Салахов; 2) Сүз уңаеннан; җае чыкканда. *Боларны мин «үтеп барышлый» гына тәкрарлыйм.* А.Хәлим; 3) Читтән торып, якыннан белмичә; белгеч булмаган хәлдә

**ҮТЕ́П-СҮТЕП** *рәв.* Ара-тирә һәм берөзлексез, арлы-бирле хәрәкәт итеп. *Юллар тузанлы, машиналар үтеп-сүтеп торалар.* А.Гыйләҗев. *Булмә аша тегендә-монда гел үтеп-сүтеп йөриләр, әмма монда Хайтовны хөрмәт итүләре әллә кайдан күренеп тора.* Т.Әйди. *Үтеп-сүтеп китүчеләр аңа әллә ни артык әһәмият бирмәделәр.* Л.Лерон

**ҮТЕРГЕЧ** *с.* **1.** 1) Үтерә торган; дәвасыз. *Тик менә кешеләрнең үтергеч бомбаларны, аяусыз пуляларны, Күктән әйләндереп, үз башларына яудырулары аяныч.* Р.Фәйзуллин. *Ул һәрвакыт караңгы чырай белән йөрүче бу егеткә – Афанасьевка үтергеч доза бирергә кушты.* Ә.Сафиуллин

2) Үлем белән яный торган; бик көчле; бик тә зыянлы. *Үтергеч алышта ирләр баш салган, күбесе кире кайтмаган.* Р.Камал. *Без бүген бергә җыелдык, теләкләребез уртак, максатыбыз бер – тылдан торып дошманга үтергеч удар ясыйк.* Казан утлары

3) *күч.* Аяусыз, бетереп ташлый торган. *«Комсомольская правда» гәзитенең үз хәбәрчесе Геннадий Паушкинның үтергеч фельетоны басылып чыкмасынмы?!* Г.Гомәр. *Алар татар гәзитләреннән файда юк дип баш тарталар, дигән үтергеч җавап һәрвакыт әзер...* З.Мифтахов // Үтә ачулы; мыскыллы. *Генерал Кравец подполковникка үтергеч караш ташлады.* М.Хуҗин

4) Бик көчле, түзеп булмастай. *Я Ходай! Мондый да үтергеч авыртуны Зәкиянең моңарчы да тойганы юк иде, моннан соң да булмады бугай.* К.Булатова

5) *күч.* Бик авыр, күңел, йөрәк күтәреп булмастай. *Лена белән булган һәрбер уенчык, һәрбер бизәнү әйбере дә үтергеч сагыш хисе уята хәзер Валяда.* З.Мәхмүди

**2.** *рәв. мәгъ.* Бик, искиткеч. *О-о, су үтергеч салкындыр әле.* А.Гыйләҗев. *Үтергеч тәмле була ул мин пешергән шулпа, телегезне йотачаксыз, валлаһи ---.* Р.Батулла. *Көннәр үтергеч кыска, төннәр өч торып, өч ятып йоклар-лык озын.* Р.Сибат

**ҮТЕРЕП** *рәв.* Бик нык, чамасыз. *Авыз эче коп-коры, колак эче үтереп кычыта, бугазыннан әчегән эремчек суы тәме килә иде.* А.Гыйләҗев. *Берәүләр аны үтереп мактадылар.* А.Хәсәнов

**ҮТЕРЕШ** *и.* 1) Бер-берсен үтерү күренеше; кырылыш. *Янә суеш, үтереш башланды.* М.Әмирханов. *Ә бит хәзер кайдадыр сугыш, үтереш бара.* Б.Рәхимова

**ҮТЕРҮ** *ф.* 1) Үлек хәлгә китерү, яшәүдән туктату; һәлак итү. *Бу, Алла сакласын, акча өчен атасын да үтерер.* Г.Камал. *Ул агачның җимешләре бөтен җан ияләрен үтерә.* А.Гадел

2) *мед.* Дарулар, төрле чаралар ярдәмендә сизми торган хәлгә китерү. *--- теш нервыларын үтерү өчен, мышьяк кулланыла башлый.* Ватаным Татарстан

3) *күч.* Юк итү. *Мин сиңа кешенең үзен түгел, ә кеше күңелендәге усаллыкны, миһербансызлыкны үтерә торган агу бирдем.* Әкият. *Фашистны үтерергә җиткән көч эгоизмны үтерергә дә җитә.* Г.Кутуй

4) *күч.* Авыр, газаплы хәлгә кую, аптыраш та калдыру. *Сезне күрмәү мине һәлак итә, үтерә, җаным!* Г.Ибраһимов. *Чит җирдә әнә шундый иптәш булмау нык үтерә.* В.Имамов

5) *күч.* Бик нык әрләү, сүгү, кирәген бирү. *Сиңа чыксам, әни мине үтерә!..* Х.Камалов

6) *күч.* **үтер** *форм.* «Нишләтсәгез дә» мәгънәсендә. *Уткән ел күпме труддинем булгандыр, үтер – әйтә алмыйм.* В.Нуруллин

◊ **Үтерә сугу** Үтерерлек итеп сугу. **Үтерде генә** Кызык сөйләп яки берәр сүз әйтеп бик нык көлдерү, гаҗәпкә калдыру. *Ул сөйләгәндә көлә-көлә эчеңката. Каян сүзен таба, каһәр! Бүген дә үтерде генә инде.* В.Нуруллин. **Үтермәгән аюның тиресен тунау** Кулда булмаган байлыкны бүлү. **Үтерсә дә** Һичкемнең сүзен колакка салмау, тыңламау, үзенчә эш итү турында; суйсалар да. *--- Бүгенгә генә түзәм дә иртәгә үтерсәләр дә чыкмыйм ат куарга.* В.Нуруллин. *– Ән-некәем, ән-некәем! Кимим, үтерсәң дә кимим! – дип, бөгәрләнә-бөгәрләнә елый иде Разия.* А.Хәлим

**Үтерә бару** Тоташтан, һәммәсен үтерү. *Шуның өчен аны күргән берен үтерә барырга кирәк, ди.* Г.Ибраһимов. *Кем ничектер, ә мин исә – үзем үтерә бардым күзәнәкләрнең миндә син яшәгән өлешен.* Р.Фәйзуллин

**Үтерә башлау** Үтерергә тотыну. *[Касыймхан:] Берни дә түгел, буып үтерә башлагач, җанымны саклап калу өчен, юк гаепне өстемә алырга мәҗбүр булдым, диярсең.* Т.Гыйззәт. *У-у-у-ул мине үтерә ба-а-а-ашлады, коткарыгыз...* Г.Каюмов

**Үтерә килү** Күптәннән, әлегә кадәр үтерү. *Төрки болгарлары элек-электән Төн илләренә үтеп керергә тырышкан сәүдәгәрләрне үтерә килгәннәр.* М.Хәбибуллин. *Сез һәрвакыт гөнаһсызларны үтерә килдегез!* Р.Батулла

**Үтерә тору** Рәттән булган берсен үтерү. *--- тагын әллә кайлардан әллә кайларга йөри-йөри дөбер-шатыр кыдыра, кыздыра да яндыра, бетерә дә үтерә торгач, әлеге дә баягы Сугыш Чукмары арган-талган, алҗыган-талчыккан ----.* Ә.Гаффар. *Ул урынны немецлар күреп тора, күрәсең, турыга атып, безнең гаскәрне җәрәхәтли, үтерә тора.* Гасырлар авазы

**Үтереп бару** Һәммәсен рәттән үтерү. *Грек мифологиясендәге амазонкалар кебек, хатын-кызларыбыз ир затларын бөтенләй кырып бетереп, ир җенесендәге яңа туган һәр баланы үтереп барырга җыенмыйлар төсле әлегә.* Н.Шәфигуллин. *--- Хак Тәгалә --- җен кавеме арасына бер-бер артлы сигез йөз пәйгамбәрне җибәрде, әмма аларны болар үтереп бардылар ---.* Ф.Яхин

**Үтереп бетерү** Барысын да үтерү; күпләп үтерү. *Барлык яхшы кешеләребезне үтереп бетерәләр, күрәсең!* Г.Ибраһимов. *Ә менә аның белән бергә әсирлектә булган алтмышлап бүтән иптәшләренең барысын атып үтереп бетергәннәр!* В.Нуруллин

**Үтереп йөрү** Күпмедер вакыт дәвамында үтерү. *Фәнирә үзенең Казанга килгән чагын сөйли, алтмыш дүртенче елның декабрендә кеше үтереп йөрүче Ионесянны, хатын-кызны талап, куркытып йөргән тагын берәүне тоткан чак икән.* Р.Кәрами

**Үтереп кую** Алдан үтерү; көтмәгәндә үтерү. *Соңгы абзацта гына төп героен үтереп куйган.* М.Галиев. *Белербелмәс кагылып, чынлап та үтереп куюыбыз бар.* Ф.Бәйрәмова

**Үтереп ташлау** Нәфрәтләнеп, кызулык яки ялгышлык белән үтерү. *Үтереп ташлаганнармы әллә аны?..* А.Гыйләҗев. *Игорь кенәзне үтереп ташладылар анда.* В.Имамов

**Үтереп тору** Даими, өзлексез үтерү; әле, хәзер үтерү. *Шушы мәет өчен немецлар тиреслек янынннан узучыларны автоматтан атып үтереп торалар.* И.Гази. *Туасы ихтирамымны аның мактануы үтереп тора.* М.Юныс

**ҮТЕРҮЧЕ** *и.* Кеше үтергән кеше; катил; кан кыючы. *Үзе йөгереп ишеккә бара; чыгам дигәндә, биш-алты ярлы крәстиән кыйнап, суккалап, акыртып ике үтерүчене төрткәләп кертәләр.* Г.Ибраһимов. – --- *Әгәр дә үтерүчене таба алмасам, минем урыным эчке эшләр бүлегендә түгел, – диде.* А.Нәҗми

**ҮТЕЧ** *и. сөйл.* Әйберләтә яки акчалата вак бурыч, әҗәт. *Сирәк күрешсәләр дә, алар тыштан җылы мөнәсәбәтләрен сакладылар, йомыш-кара төшкәндә, үтечкә акча кирәк чагында еш кына Мудрый катына бардылар.* А.Гыйләҗев. *Шуны калхузга керми йөргән җыен ярлы-ябагайга үтечкә өләшәбез.* В.Имамов

**ҮТЕШЛИ** *рәв.* Юл уңаенда, үтеп барышлый. *Тын бугаздан үтешли, тавыш коралын дерелдәтеп, тавыш чыгарта.* Г.Алпаров. *Ул, телсез, аңсыз булып, әле Хәлимгә, әле теге таныш тамгага карап торды-торды да, бер сүз эндәшминитми, йөгерә-атлый, алачык ягына ашыкты, үтешли, кое бурасы янында тукталды ---.* Г.Гыйльманов

**ҮТИ́-ҮТИ** *ы.* Үрдәкләрне чакыру сүзе. *Үти-үти, үрдәкләрем, Апакларым, күмәкләрем, Нихәлсез, дүдәкләрем?* Н.Арсланов

**ҮТКӘЗҮ** *ф. к.* **уткәрү**. *Тагын ашыгыч каерып ала, тагын бер кат үткәзә, җепне төенли дә: «Я, кәпирәтивкә ярар» [– ди].* Г.Ибраһимов. *Дәртләнә дә биеп китә, Иелеп, әйләнгәләп. Ах, үткәзеп бии, диләр, Әйдә, әйдә, эрет бер!* Л.Зөлкарнәй

**ҮТКӘН** *с.* **1.** 1) Кайчандыр булып узган, артта калган, үткән хәлләр

2) *лингв.* Сөйләм моментыннан алда булган эш-хәлне белдергән (заман)

**2.** *и. мәгъ.* Кайчандыр үтеп киткән вакыт; шул вакытта булган вакыйгалар, күңелдә калган кешеләр. *Ләкин үткәнне барыбер кайтарып булмый, хәзер төннәрен илгә «кара козгыннар» хуҗа түгел, һәрхәлдә, ачыктан-ачык законсызлыкка бармыйлар сыман.* А.Тимергалин. *Аның бар булганы: асылы, хисләре, җаны, үткәне, киләчәге – барысы да шушы сүзләргә салынган.* А.Мансуров

**ҮТКӘРГЕЧ** *и.* **1.** 1) Җылылык, тавыш, электр тогын үзе аша яхшы үткәрә торган матдә

2) Шундый мәтдәдән ясалган деталь яки җиһаз. *Яңа җиһаз ниндидер ялтырап торган тартмасыннан һәм бер өем үткәргечләрдән тора иде.* В.Исламетдин. *Сигезле дип аталган (зигзаг антенна) антеннаны ясау өчен, торбалар кирәкми. Аның өчен алюминий үткәргечләр генә кулланыла.* Р.Зарипов

3) Электр энергиясе, сигнализация, элемтә сигналлары һ.б.ш.ны үткәрү өчен махсус система. *Хлоры очып бетсен өчен, үткәргечтән суны алдан ук агызып куялар.* Мәдәни җомга

4) *махс.* Нейроннар чылбырыннан торган һәм төп эше мәгълүматны рецептордан зур ми кабыгына илтүдән гыйбарәт нерв юлы. *Минем эче исә ак һәм соры төстәге матдә белән тулган. Ак матдә эчендә баш миен арка мие белән тоташтыручы махсус үткәргечләр бар, шундый ук үткәргечләр минем башка бүлекләрен дә тоташтырып тора.* Ф.Бәйрәмова

5) *күч.* Берәр фикерне, карашны таратучы, башкаларга җиткерүче кеше. --- *сәләтле шаулы шәкертләр табып, Акчура аларны үз үткәргечләренә әйләндерә.* М.Гайнетдин

**2.** *с. мәгъ. махс.* 1) Электр тогын үткәрә торган

2) Туклыклы матдәләрне организмда хәрәкәт иттерә торган. *Үсемлекләрдә – ясалгы, төп, япма, механик һәм үткәргеч тукымалар, хайваннарда эпителиаль, тоташтыргыч, мускул һәм нерв тукымалары була.* Биология

**ҮТКӘРЕП** *рәв.* 1) Үткәнче, мул итеп (су сибү, яңгыр яву тур.)

2) Өзеп кенә; катгый итеп. *Вера Павловна, үткәреп, ни дә әйтә алмады ---.* А.Гыйләҗев

**ҮТКӘРҮ** I *ф.* 1) Тоткарлыксыз үтеп китәргә, алга, эчкә узарга мөмкинлек бирү. *Машиналар кара-каршы очрашканда, алданрак килүчене үткәреп, күпер башында туктап көтәләр иде.* А.Гыйләҗев. *Дошманны пайтәхеткә барыбер үткәрмәбез.* В.Имамов

2) Тоткарлыклар, каршылыклар аша үтәргә ярдәм итү, мөмкинлек белән тәэмин итү. *Китап әйткән: гөнаһсыз золым кылынган кешене сыйрат күпереннән яшен кеби үткәрер, дигән.* Г.Исхакый

3) Берәр нәрсәне ике арада йөртү, бер яктан икенчесенә китереп җиткерү. *Үкчәм идәндә, бармак очларым һавада, ике арада яшен йөртәм, үч ташкыны үткәрәм.* А.Гыйләҗев

4) Берәр нәрсәгә бәйләп, бер яктан икенче якка тарттыру. *Тагы тиз-тиз кадаклар кагып, җеп үткәрделәр; чыбылдык кияү белән кызның ятагы өстенә менеп асылды.* Г.Ибраһимов

5) Берәр аралык, тишек, ярык һ.б.ш. аша бер яктан икенче якка чыгару. *Аннары беренче канатны, бакыр чүкеч белән сугып, балдак аркылы үткәрде.* Г.Әпсәләмов. *Әтисенең зур сатин трусигына резинка үткәргәч, шаровар булды.* З.Кадыйрова

6) Кадап, тишеп, икенче якка чыгару. *Кадакны тактаның икенче ягына үткәрү*

7) Берәр нинди җайланма, аппарат, конвейердан ваклап, бутап, чистартып һ.б. рәвешле чыгару. *Шуны Мәгузә килен кул тегермәненнән үткәреп ярма иткән дә боткасын пешергән.* З.Зәйнуллин. *– Баздагы чүп-чарны иләк аша үткәреп булса да табарга! – диде Таймас тәвәккәл кыяфәттә.* А.Тимергалин

8) Ротатор, ксерокс кебек махсус аппаратлар ярдәмендә нөсхәләрне күбәйтү. *Петуховның конференциядә укырга тиешле докладын кырыкмасакырык кат төзәтеп, ротаторлар аша үткәрделәр.* В.Имамов. *Эш кәгазьләрен ксерокстан үткәрү*

9) Озын нәрсәләрне билгеле бер урында сузу; челтәргә тоташтыру. --- *авылга электр кертик, радио үткәртик дип, Куралык халкы Ханәфине бимазалаудан туктаячак иде.* В.Нуруллин. *Авылда водопровод үткәрәләр – син юк.* А.Гыйләҗев. *Инженер сметадан чыкмый, тимерьюлын Уральскига кадәр үткәрә.* В.Ильясов

10) Сызу. *Әгәр планда нокта куеп, аннан өскә сызык үткәрсәк, төньяк юнәлешне күрсәткән сурәт килеп чыга ---.* Башлангыч география курсы

11) Нинди дә булса чараларны яисә эшне башкарып чыгу. *Чәчәкләр башлыгы бик зур ярыш үткәрергә булган.* А.Алиш. *Нинди генә дарулар тәкъдим итеп карамадык без аңа, гипноз сеанслары үткәрдек, уколлар алды, санаторийга да җибәрдек, файдасы табылмады.* А.Гыйләҗев

12) Нәрсәне дә булса тормышка ашыру, законлаштыру. *Белемен камилләштерү, ислам мәгърифәте үзәкләре*

*белән танышу һәм шул нигездә татар мәдрәсәләре эшенә реформа үткәрергә әзерләнү өчен, ул яңадан читкә чыгып китә ---.* А.Тимергалин

13) Сеңдерү, үзең аша үтеп чыгарга бирү. *Ул көнне дөньяда миннән дә бәхетле кеше юк, чөнки минем теләсә нинди пычракны ерып йөрсәң дә бер тамчы су үткәрми торган күн башлы кирза итегем бар иде.* В.Нуруллин

14) Билгеләү. *Этник берлекнең төп типлары арасында этносның күчмә халәтләре булган, алар арасындагы чикләрне кайвакыт төгәл үткәреп булмый ---.* Б.Хәмидуллин

15) Электр тогы, радио сигналы һ.б.ш.ны тапшыру. *Аның магнит үзлекләре юк, электр тогын үткәрми.* А.Тимергалин. *Аның эчендә туендыру кабеле һәм импульслар үткәрә торган оптосүс үтә.* В.Исламетдин

16) Торбалар буенча сибелүчән, сыеклык, газ хәлендәге нәрсәләрне ерак араларга хәрәкәт иттерү. *Тиз арада, шахтадан төньяк-көнчыгышка таба терекөмеш үткәрү өчен, торба суздылар.* А.Толстой

17) *күч.* Нәрсәне дә булса куллануга кертергә, эшкә җибәрергә рөхсәт бирү; уздыру. *--- тәрәккыйпәрвәр блок Думада ни эшләргә теләсә, шуны эшли, нинди ляихәне үткәрергә теләсә, шуны үткәрә, нинди законны ясарга каршы килсә, шуңарга ирек бирми иде.* Г.Исхакый. *Булатов аңа үз планын үткәрергә ирек бирде.* А.Алиш

18) *күч.* Әзлекле рәвештә чагылдыру, күрсәтү, тәкъдим итү. *Ул легион командованиесе рөхсәт иткән гадәти пропаганда сәгатьләрендә дә совет яклы фикер үткәрергә җай таба.* Г.Әпсәләмов. *М. Әхмәтҗанов «әдернә җәя»нең исемен Төркиядәге Әдернә шәһәре исеме белән бәйли (бу җәянең конструкциясе Әдернәдә камилләштерелгән дигән фикерне үткәрә, ләкин фикерен нигезләп җиткерми).* А.Тимергалин

19) *күч.* Күпмедер вакыт дәвамында кайдадыр яшәү, булу. *Көнебезне һәм төнебезне хезмәт белән үткәрәбез, сабан төсле, туфракны күтәрәбез, өске катын аска төшерәбез, аскы катын өскә менгерәбез.* А.Алиш. *Без әтиең белән бик матур еллар үткәрдек.* А.Гыйләҗев

20) *күч.* Нинди дә булса авыру, хис кичерү, кайгы күтәрү. *Бу шатлыкны үткәрергә котым калмады.* Г.Исхакый. *--- аның иптәшләре бары да мондый фаҗигаларны үткәргәннәр, кайберләре, җиңелеп, аталар сүзенә буйсынганнар да иде.* Г.Ибраһимов

21) *күч.* Берәр хисне, уңай яки тискәре хәлне билгеле рәвештә кичерү, кабул итү. *Кешегә зурлаганны күтәрерлек, хурлаганны үткәрерлек тә акылсабырлык кирәк.* Г. Хөсәенов. *Үзенең хәле кыл өстендә торганлыктан, Саимә ирен кимүләрне, өчен уздыруларны аңы, акылы аша үткәрә алмады.* Г.Галиева *Боларның барысын да бер мизгел эчендә күңеленнән үткәрде ул.* А.Нәҗми

22) *күч.* Күңелгә бик нык тәэсир итү; йөрәккә җиткерү; аңга, башка сеңдерү. *Нindидер җитешсезлегең бар икән, җаныңа үткәреп әйтә дә бетерә.* В.Нуруллин

23) *күч.* Үсештә югарырак баскычка күтәрелергә мөмкинлек, рөхсәт бирү; сайлау аша уздыру. *Соңгы сайлауда аны нигә волбашкармага үткәрмәделәр?* Г.Ибраһимов. *Әйттем бит мин сиңа, анда синең эше авыл малайларын бик үткәрмиләр, лутчы колхозда гына эшлә дип!* В.Нуруллин

24) *күч.* Билгеле сандагы кешеләрне кабул итү, техникага һ.б.ш.га хезмәт күрсәтү. *Киләсе елга аэропорт 1200 гә якын кешене үткәрәчәк дип фаразлана*

**Үткәрә бару** Һәммәсен бер-бер артлы үткәрү. *Яңа оешма комбинатның бар продукциясен үзе аша үткәрә барып, бәяләрне күтәргәннән-күтәрде.* Р.Сәгъди. *Яшьләр бүлегендәге Рәдис Ногманов бар язмаларымны да тоткарлыксыз басмага үткәрә барды.* Өмет

**Үткәрә башлау** Үткәрергә тотыну. *Шундый күңелсез хәл килеп чыкмасын өчен, кичләрен генә түгел, көндезләрен дә, абыйлар янына да кереп чыкмыйча, соңгы айларда да гел Хәмидә апаларда үткәрә башлаган идем.* В.Нуруллин. *Ул, йокы белән уяулык арасына чумып, үзе белгән бөтен кешеләрне уе аша үткәрә башлады.* А.Гыйләҗев

**Үткәрә бирү** Бернигә карамый үткәрү. *Фәрит, әнә шулай ялының күпчелек өлешен Айрат компаниясендә үткәрә биреп, яңадан диңгезгә китәргә вакыт килеп җиткәнен сизми дә калды.* Ш.Алпар

**Үткәрә килү** Әлегә кадәр үткәрү. *Без забастовкасыз, яхшылык белән дә акрынлап үз теләгебезне үткәрә килдек.* Ш.Камал. *Моннан тагын бер тапкыр шул аңлашыла: Г. Исхакый иҗатының беренче чорында, мәгърифәтчелек тарафдары буларак, әдәбият ярдәмендә укучыларның холкын тәрбияләү бурычын куя һәм шул максатын эзлекле рәвештә үткәрә килә.* Татар әдәбияты

**Үткәрә тору** Бер-бер артлы үткәрү. *Жан моннан шундый нәтиҗә ясады: Ганс Штрубэ, мөгаен, үзенә әшнә булган сәүдәгәрләрнең товарын начар сыйфатлы булуын белгән көенчә үткәрә тора, ул шуны тели.* Ш.Рәкыйпов. *Без үзебезнең егетләребез белән тыныч кына вакытларны үткәрә тордык.* Р.Гаязетдин

**Үткәреп алу** Тиз арада үткәрү. *– Даваегыз әле, Сабир, өчәүләп теге заводка хат язып салыйк, бүгенге собраниедә үткәреп тә алырбыз.* А.Алиш. *Шуңа күрә азрак тикшерү үткәреп алырга туры килде.* В.Нуруллин

**Үткәреп бетерү** Тулысынча үткәрү. *[Җәйге көннәр,] Эшсез торсаң, тагын да озын, үткәреп бетерә алмаслык булып күренәләр.* А.Алиш. *Нинди бәхеткә тарганын белә белүен, әмма бу шатлыксөенечен аң-зиһене аша үткәреп бетерә алмый иде әле.* Г.Гыйльманов

**Үткәреп җибәрү** Бердән үткәрү; үз вакыты белән үткәрү; җайлы гына үткәрү. *Авыр сүз әйткән булсам, йөрәгеңдә калдырма, үткәреп җибәр, ярармы?!* А.Гыйләҗев. *Урак өсте – елга бер килә торган бөек мәшәкать, аны сызланмыйча үткәреп җибәрергә кирәк, дип исәпләгән Сәдит, кем әйтмешли, алны да, ялны да белми эшләде.* А.Хәлим

**Үткәреп йөрү** Әле үткәрү. *--- Тимучин бу вакытта, үзе хуҗа булып алган Гәрәйләр олысының иң чибәр кызы Сөркәктәнәне киленлеккә алып, төпчек улы Тулиның туен үткәреп йөри иде инде.* В.Имамов. *Ире икенче шәһәрдә, табибларның белемен күтәрү курслары үткәреп йөри.* М.Маликова

**Үткәреп килү** Шушы вакытка кадәр эзлекле рәвештә үткәрү. *Аннан җинаятьчеләрнең үзләрен берәм-берәм анализдан үткәреп килеп, иң соң төп, үзәк фигура булган Вәли Хәсәновка туктады.* Г.Ибраһимов. *Мәсәлән, без 10 ел рәттән «Тургай» җыр конкурсы үткәреп киләбез Чаллы шәһәрендә.* Р.Вәлиев

**Үткәреп кую** Тиз арада үткәрү; алдан үткәрү. *Болай авыз ачып йөрсәк, үткәреп куюлары да ихтимал.* З.Мәхмүди. *Июньнең унысына кадәр Сабантуйларны үткәреп куясың да, аннары ура кычкырып эшләргә дә эшләргә!* Р.Зарипов

**Үткәреп тору** Даими, бер-бер артлы үткәрү; әле, хәзер үткәрү. *Инвалидларны ул елларда ике елга бер Казанга дәшеп, врач комиссиясе үткәреп*

*торалар.* В.Нуруллин. *Офицерлар хәрби өйрәнүләрне үткәреп кенә торганнар.* В.Гали

**Үткәреп чыгу** Барысын да үткәрү, тулысынча, башыннан ахырына кадәр үткәрү. *Үзләренә килеп йөри торган кызларны тагын берничә кат хыял аша үткәреп чыкты.* А.Алиш. *Минем тормыш иптәшемнең сеңлесе үзебез өчен генә дип корпоратив алып барырга тәгъдим иткән иде, мин, ике дә уйламый сценарий язып, бәйрәм чарасын үткәреп чыктым.* Байрак

**Үткәреп яту** *к. сөйл.* **үткәреп тору**. *Менә шундый хыяллар белән янып, өченче җыелышны үткәреп ятканда, авыл ягыннан берәүнең йөгереп килгәне күренде.* Г.Ибраһимов. *Сез нәрсә, авылыгыз белән чөгендер басуына бармый, Сабан туе үткәреп ятасыз.* Д.Салихов

**ҮТКӘРҮ** II *ф. диал.* Үткенләү. *Ичмасам, үткәр бритваңны!* Г.Исхакый

**ҮТКӘРҮЧӘН** *с. махс.* Үзе аша нәрсәдер (мәс., электр, су һ.б.ш.) үткәрә торган. *Югары үзле нефть чыгару, түбән үткәрүчән туплагычлы һәм катламташлы нефть ятмаларын эшкәртү өлкәсенә инновацияләр кертү актуаль мәсьәләләрнең берсе булып кала.* Казан утлары. *Никель исә ясалма тирене нык һәм үткәрүчән итә.* Әлмәт таңнары

**ҮТКӘРҮЧӘНЛЕК** *и.* Үткәрүчән булу; үткәрү дәрәҗәсе. --- *һәр нефть ятмасының геологик хәлен, аның мөмкинлекләрен, тау токымнарының үткәрүчәнлеген, нефтькә никадәр бай булуын --- һ.б.ны исәпләп, өйрәнеп чыгарга кирәк булды.* М.Зарипов. *Ярымүткәргечнең үткәрүчәнлек зонасындагы ирекле электроннар коллективы (шулай ук валентлык зонасындагы «тишемнәр» дә) «электрон газы» дип исәпләнә.* Фән һәм тел

**ҮТКЕЛ** *и.* 1) Тау араларындагы тар юл. *Без аның белән таулар ярата идек. Марух дигән үткелләрне кичтек.* Ә.Гаффар. *Пешавардан Җәләлабадка барышлый икенче тапкыр ял итәргә тукталганнан соң башланган Хәйбәр үткелен ул чит ил сәяхәтчеләре арасында беренчеләрдән булып тасвирлый.* А.Тимергалин

2) Елга кичүе. *Белми калсам тирән кичүләрнең Үткелләре кайда икәнен, Йөкләремне чылатмый кичәргә Ленин белән киңәш итәмен.* С.Кудаш

3) *күч.* Тормыштагы кыенлык, рухи көч таләп итә торган мизгел. ---*хәятта тормыш юлының иң текә үткелләрен, хәтәр борылмаларын кичкән чагында да сине һәлакәттән йолып кала алырлык, сүнәм-сүнәм дигәндә дә күкрәгеңне утлы күмер кебек яндырып-өтеп торырлык бер бөек көч барлыгын тоеп-аңлап яшәү – үзе бер чиксез бәхет.* Р.Фәйзуллин

**ҮТКЕН** *с.* **1.** 1) Бик яхшы кисә, чәнчә, тишә, кыра торган; үткер. *Фрезер станоклары үзләренең үткен тешләре белән тимерләрне кырып, кирәкле хәлгә китерәләр.* А.Алиш. *Авызына әләгү белән, бик үткен бер ылыс энәсе Бүренең иренен ярып кереп китмәсенме!* Г.Гыйльманов

2) *күч.* Очлы очы чыгып торган. *Өстәвенә нәкъ елгага каратып, болгарлар яр өстенә катлы-катлы йортлар, сөңге сыман үткен очларын күккә сузган түгәрәк манаралар төзегәннәр.* В.Имамов

3) *күч.* Яхшы күрә яки ишетә торган. *Авылның иң читендәге фәкыйрь тирмәсенә кайтып, аз гына утырган иде, аның үткен колагы төн ягыннан берничә атның дөп-дөп басып килгәнен ишетте.* Г.Ибраһимов. *Ике күзем минем үткен күз, Күрә кайда дошман посканын, Ике күзем кебек ике улым Сизгер саклар илнең постларын!* А.Алиш

4) *күч.* Барысын да бик тиз сизеп ала, күрә, үтәли күрә, бер күрүдә аңлый торган; зирәк, игътибарлы. *Ул аны үзенең үткен карашы белән кисеп үтте.* А.Гадел. *Әбекәй үткен зиһене, җитезлеге белән күпләрне таң калдыра.* А.Мансуров

5) *күч.* Тәэсирле; үтемле. *Нәтиҗәдә бүгенге көн сыйфатларына бай һәм үткен сатирик комедия туган.* А.Әхмәдуллин. *Зирәк зиһен, үткен фикер, күркәм холык, тулы иман бир!* А.Хәлим. *Аяз абый дигән кеше, синең өеңә хәтле үк килеп җиткәч, матур, үткен сүзләрен тәгәрәтеп җибәрмичә калмый икән ---.* Б.Рәхимова

6) *күч.* Булдыклы, елгыр. *Арада үткен, зирәк, шаян Тургайбай бар иде.* Г.Ибраһимов. *Әнинең анасы – ерак әбинең бик үзсүзле, бөтенесен үз кулында йомарлап тотарга яратучы нык куллы үткен карчык булуын без, балалар, яхшы ук сизә идек.* Г.Бәширов

7) *күч.* Киеренке; ачык күренеп, сизелеп торган. *Кечкенә сабый бала үз анасыннан көчләп аерып алып киткәндә нинди үткен кайгы эчендә булса, Мәрхәбә киленгә дә шулай тоелды.* Г.Ибраһимов. *Газинурның күңелендәге сугыш ярсуы басылып бетмәгән иде әле, шуңа күрә аның нечкә хисле йөрәге сугыштан соң һәр солдат йөрәгендә табигый рәвештә туа торган үткен сагышны – һәлак булган яки яраланган иптәшләрен сагыну сагышын сизми иде әле.* Г.Әпсәләмов

8) *күч.* Көчле, кискен, үзәккә үтә торган. *Бер-бер тамган үткен тамчылардан Хасил була дәрья ташкыны.* З.Бәшири. *Пермь тирәсендәге таулы чыршы урманнары ышыклаган кебек була да, яланга чыккач, үткен җил битне чагып ала.* М.Галиев

9) *күч.* Кичекмәстән хәл ителергә тиеш булган, өлгергән. *Шуңа күрә парткомның бүгенге җыелышы Булат өчен дә, Гәрәй өчен дә аеруча үткен бер мәсьәлә булып күтәелгән иде.* Г.Ибраһимов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Яхшы, ачык итеп. *Газинур караңгыда мәче кебек үткен күрә, очар карлыгач кебек, тавышсыз йөри белә иде.* Г.Әпсәләмов

2) Үтемле, тәэсирле итеп. *Анлар хакында ачы вә үткен сөйли иде.* З.Һади

**ҮТКЕНӘЮ** *ф. к.* **үткенләнү**. *Гражданнар сугышыннан соң, егерменче еллар башында, идеология фронтында сыйнфый көрәш үткенәйде.* М.Хәсәнов. --- *үзегезне сынап карагыз, бәлки, сездә әлегә кадәр үзегез дә белмәгән талант ятадыр, язып карагыз, иҗат утын дөрләтеп җибәрегез, онытмагыз: каләм яза-яза үткенәя.* Идел таңнары

**Үткенәеп бетү** Бик үткенәю

**Үткенәеп китү** Кинәт үткенәю, бераз үткенәю. *– Ба, бездә кунак бар икән, – дип, аякларындагы туфлиларын дә салып тормастан алга үтте һәм бу мизгелдә үткенәеп киткән күзләре, хәтере, нидер сизенгән йөрәге Сәетне танып алдылар.* Т.Галиуллин

**Үткенәеп тору** Хәзер үткенәйгән булу. *Аның [Мусаның] --- ияк һәм борын очлары, һөҗүмгә ташланачак дала шоңкарыныкы кебек, аеруча үткенәеп тора ---.* Ш.Маннур

**Үткенәя бару** Торган саен үткенәю. *Шагыйрәнең каләме үткенәя бара, дөньяны кабул итү офыклары да киңәя.* Б.Рәхимова

**Үткенәя башлау** Үткенәергә тотыну. *Ләкин Гариф бу күтәргән мәсьәләләрне логик азагына кадәр җиткерми, мәсьәлә үткенәя башлагач, --- тизрәк башка – куркынычсызрак коллизияләр артына поса.* Ф.Хөсни

**Үткенәя төшү** Бераз үткенәю; тагын да үткенәю. *Йомшак, сабыр җил дә үткенәя төшкән, усалланган иде.* Ш.Шәйдуллин. *Аерым энҗе бөртеге үзенчә бер ямь белән җемелдәсә, ә алардан тезелгән тулы бер таҗны*

*күргәч, караш беркадәр үзгәрә, үткенәя төшә икән.* Р.Фәйзуллин

**ҮТКЕНЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **үткенләү**. *Пычаклар үткенләнгән*

2) Нечкәрү, очлаю. *Аның яңак сөякләре калкып чыккан, күзләре суырылып эчкә баткан, болай да очлырак борыны без кебек үткенләнгән иде.* А.Гыйләҗев

3) *күч.* Яхшыру, камилләшү. *Андый ят, купшы, акварель төсләрдән тукылган табигать эргәсендә хәтер үткенләнә, балачак хатирәләренә бирелү хисе көчәя икән.* Р.Вәлиев. *Өйдән чыгуга туңдыра-калтырата, ләкин бераз баргач җылынасың, атлаган саен атлыйсы килә, бит очларының кызышканын, күзләрнең үткенләнгәнен – гомумән чибәрләнеп киткәнеңне тоясың.* М.Маликова

4) *күч.* Чаялану; җитезләнү; усаллану. *Соңгы еллардагы үткенләнгән сыйнфый дошманның сугышы безне ут белән су кебек каршы куйса да, миләрнең, йөрәкләрнең юллары тагы бергә кушылып ага башлады бугай.* Г.Ибраһимов

5) *күч.* Киеренке хәлгә килү, ачыграк сизелеп, күренеп тора башлау. *Баштарак дәрманы кузгалса да, бераз тынычлана төшкән, уйлары үткенләнде һәм шул тиклем зур акчаны бер дә юктан гына тоттырып җибәрүләренә бик ышанасы да килмәде.* М.Кәбиров

6) *күч.* Остару, үсү. *Каләме елдан-ел үткенләнә, камилләнә, үз колоритын таба килә.* Т.Галиуллин. --- *Татарстан нефтьчеләре коллективында шулар тудырган иҗади атмосферада Асия шикелле шунда туып үскән яшьләрнең тикшеренү, эзләнү һәм гомумиләштерү сәләте үткенләнә.* Х.Зарипов

**Үткенләнә бару** Торган саен күбрәк, яхшырак үткенләнү. *Моңа үзләре хурланалар, хурланган саен, ул үткенләнә бара, аның саен ныграк ябыша бара.* Г.Ибраһимов. *Әдипнең каләме елдан-ел үткенләнә барды, иҗади куәте үсте.* Казан утлары

**Үткенләнә башлау** Үткенләнергә тотыну

**Үткенләнә төшү** Бераз үткенләнү. *Ләкин аның ун еллык революцион тәҗрибәсе сак булырга өнди, катлаулы вакыйгаларда чарланган сизгерлеге тагы да киеренкеләнә, тагы да үткенләнә төшкән иде.* А.Расих. --- *гүя меңләгән сөлектәй ир-ат һәм хатын-кыз, берсе берсенә җепсез бәйләнеп, Өязе тугайларында пакуска төште, аларның таң чыгында тагын да яшәргән, тагын да яктыргән, каты кондырак үлән балавызында тагын да чарлана, үткенләнә төшкән чалгылары үзе бер симфония, үзе бер бөек операга торырлык җыру-пакусны бергәләп иҗат итә иде...* А.Хәлим

**Үткенләнеп бетү** Бик үткенләнү. *Өстәвенә гомумшигърият хәзинәсендә һәр халыкның меңәр еллардан бирле шомарып, үткенләнеп беткән тапкыр сүзләрен, мәкаль-әйтемнәрен, табышмак-сынауларын да онытмыйк.* Р.Фәйзуллин

**Үткенләнеп җитү** *к.* **үткенләнеп бетү**. --- *сәяси адымның кая барып чыга торганын күрер дәрәҗәдә сәяси мохит киңәеп, күз озаеп, үткенләнеп җиткәне юк иде.* Г.Исхакый

**Үткенләнеп китү** Кинәт үткенләнү; соңгы арада үткенләнү. *Сөләйман үткенләнеп китә: – Ничек болай булдың дисең, Сәхип?* Г.Ибраһимов. *Ирешүен ирештем мин максатка, тик Саимәмнең теле дә ябыкты димме, бик үткенләнеп китте.* Ә.Хәсәнов

**Үткенләнеп тору** Даими үткенләнү. *Белгәнегезчә, тик тормаган, гел җир сөргән төрән генә һәрвакыт үткенләнеп тора.* Г.Каюмов

**ҮТКЕНЛӘ́Ү** *ф.* 1) Кадый, кисә торган нәрсәләрне кайрап үткен итү. *Берәүләр пычкы үткенли, балта кайрый, кадаклар салынган тартмаларын актара, хатын-кыз көнбагыш чиртә, кычкырыш, шау-шу, барысы да берьюлы сөйләшкән кебек, будка эче колхоз базарыдай гөж килеп тора.* Р.Кәрами. *Ул, бүкәнгә утырып, зең-зең пычкы я балта үткенли, үзе төш күргән шикелле хыяллана.* А.Тимергалин

2) *күч.* Яхшырту, осталыгын арттыру, камилләштерү. *Ул аларга аң һәм рух бирә, Акылларын ныграк үткенләп. Киртәләрдә туктап калдырмыйча Алып чыга хәтәр үткелдән...* Казан утлары

**Үткенләп алу** Тиз генә үткенләү; бераз үткенләү. *[Рәхилә:] Син азрак җылый тор, мин аз-маз пәкемне үткенләп алыйм, дип әйтте ди парикмахер муены киселгән бер абзыйга.* А.Гыйләҗев. *Бер агачны кисеп чыгаруга, чылбырны янә кайрап, үткенләп алырга туры килә.* Хезмәт даны

**Үткенләп бетерү** Барысын да үткенләү

**Үткенләп җибәрү** Берникадәр үткенләү. *Тырманың тешләрен үткенләп җибәрү*

**Үткенләп кую** Алдан үткенләү. *Ярый әле беркөн кул белән әйләндерә торган чарны табып, тагаракка су салып, әтисе белән балталарны үткенләп куйганнар иде.* Р.Кәрами. --- *малае Таһирның биле кузгалды. Гали пәкеседәй чүкеп, үткенләп куйган өч чалгы, бөтен авыл печән чапканда, тик торды.* Ф.Садриев

**Үткенләп тору** Еш, һәрвакыт үткенләү; хәзер үткенләү. *Мондый олы шәхесләр белән еш очрашып, аларның төпле фикерләрен тыңлап, үз уй-теләкләреңне үткенләп торсаң, начар булмас иде ул.* Н.Гариф. *Граммофон инәсен әти үзе гел кайракта үткенләп тора.* Р.Зарипов

**Үткенләп чыгу** Барысын да үткенләү

**Үткенли бару** Торган саен үткенрәк итү. *Киресенчә, каләмен чарлый, үткенли генә бара.* Ватаным Татарстан

**Үткенли башлау** Үткенләргә тотыну. *Аннан тегенең ботында бритвасын үткенли башлаган.* Ватаным Татарстан

**Үткенли төшү** Тагын да үткенләү. *Каләмен азрак үткенли төшсә, аның даһи әсәрләр бирә алуына бер тамчы шик юк.* Г.Афзал

**ҮТКЕНЛЕК** *и.* Үткен булу сыйфаты. *Ләкин ул яңа, ул үтә кызык нәрсәләр бик күбәеп китсә, алар үзләренең күплекләре белән кешене басалар, тойгыларының үткенлеген киметәләр, ахыр килеп аның күңелендә гамьсезлек тудыралар.* Г.Әпсәләмов. *Аның карашының үткенлеген, гадәти түгеллеген Нәҗип кергәч үк чамалаган иде, хәзер, күзгә-күз очрашкач, сискәнеп, югалып калды.* А.Гыйләҗев

**ҮТКЕР** *с. к.* **үткен**. *Үзе кечкенә үткер күзләре белән безгә шулхәтле горур, буйсынмас карый, әйтерсең без – аның дошманы.* Г.Әпсәләмов. *Абзасыннан калган эш кораллары: үткер балта-пычкылар, өтергеләр, ышкылар – һәммәсе эшкә ярады.* А.Гыйләҗев

**ҮТКЕРЛӘНҮ** *ф. к.* **үткенләнү**. *Өязгә чыгып йөргән кеше ил-дөнья күрә, урыс белән аралаша, үткерләнә, шомара.* Т.Мөбарәков. *Каләмегез тагын да үткерләнсен, иҗат чишмәгез киңәйсен, тирәнәйсен.* Туганайлар

**Үткерләнә бару** Торган саен үткерләнү. *Канун шул үк: баш калыккан саен Үткерләнә бара кайчылар.* Р.Аймәт

**Үткерләнә башлау** Үткерләнергә тотыну

**Үткерләнә төшү** Бераз үткерләнү; тагын да үткерләнү. *Ләкин итальян, француз, немец, урыс опералары, үзебезнең «Алтынчәч», «Муса Җәлил»*

*әсәрләрен, «Башмагым» музыкаль комедиясен тыңлап ләззәт алудан безнең күңелләребез байый, хисләребез үткерләнә генә төшәр иде бит.* Р.Вәлиев

**Үткерләнеп бетү** Тәмам үткерләнү

**Үткерләнеп китү** Көтмәгәндә үткерләнү; соңгы арада үткерләнү. *Зөлхәбирәнең карашы үткерләнеп китте, ул күпсанлы обой кисәкләре астыннан почмагы гына күренеп торган, зәңгәр каләм белән чуарланган кәгазьне үзенә таба тартты.* Казан утлары

**Үткерләнеп тору** Даими үткерләнү; үткер булып күренү

**ҮТКЕРЛӘ́Ү** *ф. к.* **үткенләү**. *Ул аны, иптәшләреннән качып, өч көн ташка ышкып үткерләде.* Г.Әпсәләмов. *Кылычларыгызны яхшылап чарда тотыгыз, үткерләгез!* З.Зәйнуллин

**Үткерләп алу** Тиз арада үткерләү. *Сусадым, чәй дә эчәрмен, бераз ял итәрмен, балтаны да үткерләп алырмын, дип, Әнәс өйгә керә.* Туган як

**Үткерләп бетерү** Барысын да үткерләү; яхшылап үткерләү. *«Песи ашый башлап ташлаган» кайрак пәкене бик үк үткерләп бетерә алмаган, ахры, һәр учма чәч белән тешләрне кысып, күзләрне чытырдатып йомып кына саубуллашырга туры килә.* Р.Төхфәтуллин

**Үткерләп җибәрү** Берникадәр үткерләү

**Үткерләп кую** Алдан үткерләү. *Хуҗасына безнең монда икәнлекне хәбәр итеп, кирәк булса, киллерларын чакыртып, мылтыкны корып, пычакны үткерләп куярлык вакыт бирелде.* Т.Галиуллин. *Хәнҗәр әзерләдем. Аны көн саен үткерләп куя идем.* Г.Гыйльманов

**Үткерләп тору** Һәрдаим, еш үткерләү; әле, хәзер үткерләү. *Билгесез бур коралларның берсенә дә кагылмаган, шул балтаны гына алган, күз карасыдай саклап, чәч пәкеседәй гел үткерләп кенә торган кадерле балтаны гына алган.* Н.Фәттах

**Үткерләп чыгу** Барысын да тоташтан үткерләү

**Үткерли башлау** Үткерләргә тотыну. *Ишекләргә заказ кимесә, вактөяк мәшәкате чыгып тора, һич тә булмаса, тимер, агач тузаны кунган станокларны, идәнне себерергә тотына, үзенең, иптәшләренең коралларын үткерли башлый.* Д.Булатова

**Үткерли төшү** Тагын да үткерләү; бераз үткерләү

**ҮТКЕРЛЕК** *и. к.* **үткенлек**. *Ләкин мәсәлне бөтен реальлеге, политик үткерлеге һәм психологизмы белән рус әдәбиятында тудырган кеше Иван Андреевич Крылов була.* М.Мәһдиев. *Теле белән тегермән тарта, акылы белән дөнья кайната, үткерлеге белән кылдан нечкә, кылычтан үткер сыйрат күперен үтә белә.* С.Поварисов

**ҮТ КУЫГЫ** *и. анат.* Үт җыела торган әгъза. *Менә нәкъ шул вакытта бөер, бавыр, үт куыгы гөрләп эшли башлый, һәм бу табигый да, чөнки табигать аларны, шулай гөрләп эшләсен өчен, синең гәүдәңнең эченә беркетеп, урнаштырып чыккан.* М.Мәһдиев. *Ул шүресен шунда тыгып өрергә керешә, Миңзаһитның эче тартылып күбә, үпкә-йөрәкләре, бавыр-бөерләре, үт куыгы таштай кабара.* Ф.Садриев

**ҮТЛӘ́ГӘНЧЕ** *рәв.* Бик күп итеп; туйганчы, гарык булганчы. *Әрәмтамакларны үтләгәнче ашатып яттың.* Ә.Мушинский

**ҮТЛӘТҮ** *ф. к.* **үтләү**. *Әмма ни гаҗәп: кызык тамашалар күпкә киткәч үтләтә икән.* Ф.Яруллин. *Бик күп эчә алмыйм шул мин аны, үтләтә.* З.Зәйнуллин

**Үтләтә башлау** Үтләтергә тотыну. – *Сине яшь малайлар үтләтә башлаган, ахры.* М.Әмирханов

**Үтләтеп бетерү** Тәмам үтләтү. *Ул кадәр баллы нәрсә булгач, бик төче нәрсә булып, безне бөтенләй үтләтеп бетермәсә ярар иде дип куркам.* Г.Камал. *Мондый мәгълүмат инде безне үтләтеп бетерде ---.* Татарстан яшьләре

**Үтләтеп җибәрү** Бераз, кинәт үтләтү. *Каймакка манчылган симез калҗалар үтләтеп җибәрсә, Сәләхнең спирты коткарды.* Ф.Яруллин

**ҮТЛӘ́Ү** *ф.* 1) Бик күп яки бик майлы ризык ашаганнан соң күңел болгану, косасы килү. *Күршеләре җәлләп сөт биргәч, сөтле аш ашыйлар да, чирләп, үтләп, өй эчләре белән авырып алалар.* М.Мәһдиев. *Эч буш булмасын дип ашыйбыз. Әмма ашказаны балыктан үтләгән – кабул итми.* З.Мәхмүди

2) *күч.* Тәмам тую, ару, күрә, ишетә алмас булу. *Теге вакыт Зөләйхадан шактый үтләп туктаган иде.* Ф.Яруллин

3) *күч.* Азыну, зәһәрләнү. *Бәяләр дә шашынды, бәяләрдән битәр түрәләр азынды, байлыкларына чыдаша алмый үтләделәр.* Н.Хәсәнов

**Үтләп алу** Бераз гына вакыт үтләү, аз гына үтләү

**Үтләп бетү** Бик нык үтләү. *Ә көн саен радио тыңлаучыларның «догалардан» инде гарык булып, үтләп бетүендә аның да, радионың да ни эше бар...* Казан утлары

**Үтләп тору** Әле үтләү

**Үтли башлау** Үтләү билгеләре яңа гына күренү. *Югыйсә гомер буе бер хатын белән генә торып үтли башлаган кешеләр, бигрәк тә язучының каләмдәш иптәшләре, хикәя белән үтә дә нык кызыксынып, моның өчен аның авторына даһи дигән титулны тагарга әзер торалар ---.* Ф.Хөсни

**Үтли төшү** Бераз гына үтләү

**ҮТЛӘШҮ** *ф.* 1) Үзләштерелү, сеңү (азык тур). *Май бик тизлек белән чебеннең эченә үтләште. [Чебеннең эче] --- май белән тулды.* Ак юл

2) *күч.* Үтеп керү, бик нык тәэсир итү. *Ул [көз исе], кешенең бөтен тамырларына үтләшеп, нәкъ исерткән төсле итә.* Гали Рәхим. *Арка-җилкәләргә үтләшкән яңгыр юеше йокымсырап барган тәнне туңдыра башлады.* Ш.Маннур

**ҮТЛЕ** *с.* 1) Үте булган. *Үтле һәм үтсез хайваннар*

2) *күч.* Зәһәр, усал. *Анысы да, шуклыктан бигрәк, соңгы чиккә җиткән гаҗизлектән туган үтле бер ачыну белән әйтелде шикелле.* Ф.Хөсни. *Белеп тор: явыз булсаң да, бу кадәр ачы үтле булырга ярамый.* Безнең гәҗит

**ҮТЛЕ́ ГӨМБӘ** *и. бот.* Болетачалар семьялыгыннан эшләпәсе көрән, коңгырт төсләрдәге, бик ачы, ашарга яраксыз гөмбә; *русчасы:* **желчный гриб**

**ҮТЛЕК** *и.* Зәһәрлек. *Әгәр теләсә нинди үтлеккә сәләтле фашистлар чираттагы әшәкелекләрен эшләргә генә ниятләнгән булсалар?..* Р.Мостафин

**ҮТМӘС** *с. сөйл.* 1) Чарланмаган, кайралмаган, үткенәйтелмәгән; тупасланган, кисми яисә бик начар кисә торган. *Бичара, үтмәс пычак илә кыра торгач, ияктәрен, иреннәрен тәмам кискәләп бетергән, куллары вә авызы канга буялган.* Г.Тукай. *Кибет стенасындагы кызылга буялган тактага янгыннан саклану җиһазлары – төпсез чиләк, үтмәс балта, сапсыз көрәк куелган.* Д.Салихов

2) Сатылмый яисә бик начар сатыла торган. *Аның халкы үзе берни җитештерә алмый, тегесенең үтмәс товарын гына үзләштереп ята.* З.Хөснияр. *Әллә үтмәс товарлар ташыды Лилиясе, танавы да күршенеке төсле сизгер булып чыкмады шикелле, ярты бәясенә сатып чак котыла алды ул җыйган чүпрәкләреннән.* К.Кара

◊ **Үтмәс пычак белән суйю** Уңайсыз, авыр хәлгә кую. *Тагын бер исәптә*

*хата киткән – Үтмәс пычак белән суялар: харап инде, беткән баш беткән, – Карловы Варыга куалар.* Г.Афзал. **Үтмәс пычак белән эш итү** Берәр мәсьәләдә ялгыш ысул, чара куллану турында. *Әйтергә кирәк, хәзерге ноктадан караганда, мондый гамәлләр язучының беркатлылыгы, үтмәс пычак белән эш итүе дип бәяләнергә мөмкин.* К.Гыйззәтов. **Үтмәс товар** Беркемгә кирәкмәгән нәрсә яки кеше. *Бу заманда иң үтмәс товар намус булыр иде, минемчә.* З.Мәхмүди. *Тукып торам аһарга: – Базарда да ия чыкмый Сиңа – үтмәс товарга!..* К.Булатова

**ҮТМӘСЛӘНДЕРҮ** *ф.* Үтмәс итү. *Чалгыларны үтмәсләндерүче бер генә ат кузгалагы да күренми.* А.Алиш

**ҮТМӘСЛӘ́Ү** *ф.* Тупасландыру, йөзен бетерү, үтмәс итү. *Әзмәвердәй баһадирлар еккан куе үлән чалгыларны бик тиз үтмәсли.* А.Хәйретдинова

**Үтмәсләп бетерү** Бөтенләй үтмәс итү. *Безгә дә балта-пычкыларын үтмәсләп бетергәнче нидер ясавыбызга бер сүз әйтмәде.* Хезмәт даны

**ҮТМӘСЛЕК** *и.* Үтмәс булу сыйфаты. *Товарның үтмәслеген сиземләү*

**ҮТҮ** I *ф.* **1.** 1) Нинди дә булса араны, юлны узу, бер ноктадан икенчесенә кадәр килеп җитү. *Ә Алмазның әнисе, ерак чакрымнар үтеп, алай көн саен килә алмый дәваханәгә.* А.Хәйретдинова. *Монда инде төркиләр белән кушылып атларда һәм җәяү --- Азияне аркылыга-буйга үттеләр.* А.Нәҗми

2) Берәр кем яки нәрсә яныннан узу, китү. *Трамвай үтеп китә, трамвай килеп җитә, ишекләре шап итә...* А.Хәмзин // Нинди дә булса бер объект, урын яныннан хәрәкәт итеп, шуннан ераклашу. *Тик акыл белән әни яклы булып, аныңча эшләп йөрсәм дә, иртә-кичләрен мәктәп яныннан үткән чакларда, күңел һаман шунда тарта бит, шайтан.* В.Нуруллин // Хәрәкәт итеп, билгеле бер урыннан ераклашып, аны артта калдыру. *Без, Самасыр авылын үтеп, аэропорт тирәләренә килеп җиткәндә, инде төш авышкан иде.* В.Нуруллин. *Без Чаллыны үтеп бераз баргач та, шәһәргә тоташкан диярлек зур гына авылга килеп кердек һәм бер өй янына барып туктадык.* А.Нәҗми

3) Берәр киртә, тоткарлык, чик һ.б.ны кичеп чыгу, артта калдыру. *– Кош очып җитмәслек илләрдән, кеше аягы басмаган җирләрдән, җиде диңгез үтеп, шарлавыклар кичеп, минем илемә – Капкорсак патша җиренә килгән осталар остасы Бикзирәк, минем сезгә сүзем бар әзрәк, – дип әйтте, ди, Капкорсак патша.* А.Алиш. *Тауларны үтеп булыр иде, алда Тирән чокыр бар әле.* А.Гыйләҗев

4) Берәр нәрсә аша яки арасыннан керү яисә чыгу. *Куян рәшәткә арасыннан үтә алмаган, кире борылган.* А.Алиш. *Арткы ишектән үттеңме?* Ф.Садриев

5) Басып торган, утырган урыннан кузгалып, икенче урынга, эчкә юнәлү, шуңа барып җитү. *Без Җәгъфәр белән мунча хезмәткәренә ике пул акча тоттырдык та алгы чишенү бүлмәсенә үттек.* А.Тимергалин. *Алар юынып, өсләрен алыштырып, исәнләшеп түргә үттеләр.* Д.Булатова

6) Берәр нәрсәнең буеннан-буена еракка сузылып китү. *Авыл уртасыннан боргаланып-сыргаланып агым су үтә.* Г.Кутуй. *Иң зур нефть торбасы да безнең басудан үтә.* А.Тимергалин

7) Берәр катламны казып, чокып, тишеп бару. *Бораy каты доломит катламын үтеп, продуктлы горизонтка – йомшак комташка килеп керде.* Ш.Бикчурин. *Ташлы катламны үткәндә, бораулау торбаларының бер-берсенә ялганган урыннары нык кысыла, кувалда белән кыйнамыйча сүтеп ала торган түгел.* К.Кәримов

8) Үтәдән-үтә агып чыгу, саркып керү. *Яңгыр суы яка астына үтеп кергәч, лач-лач пычрак изеп, авылга кайтам.* А.Гыйләҗев. *Тула оекларга су үткән иде.* А.Хәлим

9) Эчкә, организмга керү һәм өшеткеч белән яисә җылытып тәэсир итү. *Төн болай җылы булса да, Кама җиле койрыктагы егетнең сөякләренә үтеп керде.* А.Гыйләҗев. *Туңуын алай сыңар колагын исәпләмәгәндә туңмаган иде, тик бөеренә салкын үткән бит.* З.Мурсиев. *Эченә җылы үткәч, бурлаттай кызарып чыккан Зарифа, арып-авыраеп калган гәүдәсен көчкә кузгатып, зур ягындагы диванга чыгып утырды, телевизор кабызырга үрелде.* К.Кара

10) Яктылык, нур сызылу, сибелү. *Тәрәзә капкачлары бер учма нур үтмәслек итеп ябылган, ак карга күмелеп утырган караңгы йорт тирәсендә байтак уралды.* А.Гыйләҗев. *Аннан әллә ни яктылык үтмәсә дә, ишектән өргән кебек салкын бәреп тора.* Р.Мирхәйдәров

9) Тишеп керү. *Йөрәк аша пуля үтә, Хыялларны җимереп.* Ә.Мәхмүдов

10) Ихтыяҗ булу, базарда кулланучы тарафыннан соралу, әйбәт сатылу. *Товарларыбыз үтми генә.* А.Хәсәнов. *Әйберләрең үтәме соң, әллә остаханәңне генә бизәп торалармы?* М.Әмирханов

11) Булып узу, туктау. *Яңгыр кинәт үтте, шуннан тоташ җил, эсселәр башланды.* А.Гыйләҗев. *Давыл үтте урман итәгеннән, богыллар туздылар, агачлар сынды...* Р.Зәйдулла

12) Махсус җайланмаларда эшкәртелү. *Су ул, төрле тазартулар, фильтрлар аша үтеп, пар казанына керә, анда парга әйләнә.* А.Алиш

13) Ашый алу, ашау теләге булу. *[Дружинин:] Үткәненчә ашарбыз. (Колхозчыларга карап) Үзегез дә эшләгән кебек ашагыз.* А.Алиш. *Утызлап кеше эшсез утырганда, тамактан ризык үтәме?* В.Нуруллин

14) Билгеле бер вакыт, вакыйгалар һ.б.ш. булып артта калу, узу. *Сиңа кадәр без вакытны бушка килә һәм бушка үтә дип уйлый идек.* А.Хәлим. *Тик еллар үтә, могҗизаның зурысы булмый, ә көндәлек бәләкәй могҗизаны маңгай күзе күрми...* А.Тимергалин. *Аның хакимлек чоры тиздән үтеп китәчәк.* А.Вергазов // Билгеләнгән вакыт чигенең икенче ягына чыгу. *Сәер булыр микән, йөзне үтеп, Туры килсә парлап йөрергә.* В.Галиев

15) Билгеле бер вакыт дәвамында бару һәм тәмамлану. *«Галиябану» спектакле клубта шыгрым тулы зал белән үтте.* А.Әхмәтгалиева. *Бу чорда Казанда күренекле галим, врач К.Ф. Фукс йортында әдәби кичәләр, җирле халык тарихы һәм мәдәнияте турында зур сөйләшүләр үтә.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

16) *сөйл.* Авыртудан туктау, дәваланып, авыру китү. *Дәвалаганнан соң, спазмалар үтәр.* Г.Әпсәләмов. *Үтте инде, сызламый башлады.* А.Гыйләҗев. *– Ярар, җаным, борчылма. Үтте бугай инде, – диде Мәннан тыныч кына.* Аманулла

17) *эвф.* Үлү. *Кем белә, бәлки, сиңа да Алла инсаф бирер, мөселманлыкка кайтып, иман белән дөньядан үтәрсең.* Г.Камал. *Ничек, күрдең, атаң Үз кулыңнан үтте, хуш бәпкәм!* Б.Мирзанов

18) *күч.* Конкурс, сайлаулар аша кабул ителү, раслану, алыну (тәкъдим, фикер, кандидатура һ.б.ш. тур.). *Университетка эләгер өчен, егерме сигез балл җитә, бер-ике кеше егерме җиде балл белән дә үтәчәк икән, дип сөйлиләр.*

В.Нуруллин. *Син кандидатлыкка җырлап кына үттең, инде депутат булу өчен, көрәш башлап җибәр.* В.Имамов

19) *күч.* Билгеле бер вакыт аралыгында үзләштерелергә тиешле материалны үзләштереп яисә башкарырга тиешле эшне башкарып чыгу. *Армияне үттең, яшең дә бара ...* Ш.Галиев. *Дүртенче классны ерып үтеп, койрыкка чыкты.* А.Гыйләҗев. *Ун айлык кыска вакытлы курслар үтеп, яңа чыккан поручик Алексей Иннокентьевич Антоновны егерь полкына взвод командиры итеп билгелиләр.* З.Зәйнуллин

20) *күч.* Тиз генә чагылып китү; юк булу. *Йөзеннән елмаю үтү*

21) *күч.* Күз алдына, уйга килү. *Аның кызыгып йөргән гакыллы кешеләре берсе артыннан берсе күз алдыннан үтте.* Г.Исхакый. *Балчык койма аркылы һәрвакыт сузылып карый торган күрше кызы Сәламәтханның кара йөзем кебек күзләре дә уеннан үтте.* Г.Әпсәләмов

22) *күч.* Тәэсир итү. *Шул вакытта әллә кайдан, ерактан, җанга үтә торган моңлы көй белән әкрен генә калынрак аваз ишетелә.* Гали Рәхим

23) *күч.* Нindидер авырлыклар, кайгы-хәсрәт, шатлык кичерелү. *Бу җилкәдән ниләр генә үтмәде*

24) *күч.* Тикшерүгә, котрольгә, тентүгә һ.б. чараларга дучар булу. *Үзегез беләсез, ремонттан яңа чыккан бу автобус руленә мин очраклы рәвештә генә утырдым, чөнки үземнең автобус профилактика үтә иде.* А.Тимергалин. *Медосмотр үтәргә дип кенә барган иде югыйсә.* Г.Гыйльманов

25) *күч.* Бетү, юкка чыгу (хисләр, нәрсәгәдер сәләт тур.). *Табигать тавышын, дөнья тавышын ишетәм. Балачакта һәркем ишетәдер андый тавышларны. Олыгайгач үтә ул.* Г.Гыйльманов. *Тик безнең үпкә тиз үтә, Без бит абый һәм сеңел.* В.Хәйруллина

26) *күч.* Ярарлык булу, кабул ителү; бату. *Бусы ярый, үтә*

27) *күч. юкл.* Берәр нәрсә белән чикләнү, шуннан артыгын эшләмәү яки эшли алмау. *Эш планнан ары үтмәү*

**2.** *ярд. ф. мәгъ.* Эшне икенче бер эш арасында, шул эш барышлый башкаруны белдерә. *Шулай да бер кытыршылыкны күрсәтеп үтәсе килә.* А.Тимергалин. *Сүз уңаеннан әйтеп үтү*

◊ **Үтеп-сүтеп йөрү** Тегендә-монда, әле бу, әле икенче якка еш-еш һәм туктаусыз йөрү, узып тору. *Көн дә яныннан үтеп-сүтеп йөрибез, ләкин эченә кергәнебез юк, анда ниләр барын белмибез.* Ә.Еники. *Юк, ачмыйм, бирелдә – кеше үтеп-сүтеп йөри торган җирдә ачмыйм.* Н.Әхмәдиев. **Үтеп чыккысыз** Хәл ителә алмаслык, бик авыр, кыен. *Бу ике зат арасында нindидер үтеп чыккысыз киртә, күзгә күренмәс дивар барлыгын нindидер бер эчке тоем белән аңлыйсың.* А.Тимергалин. *Алда бит әле үтеп чыккысыз гомер тавы.* М.Галиев. **Үткән дә сүткән** Күптән булган, әһәмиятен югалткан. *Алар инде әллә кайчан ук үткән, үткән дә сүткән.* Г.Бәширов. **Үткәне дә, сүткәне дә** Һәммәсе дә, барчасы; кем тели, шул. *Яше дә, карты да керде Сәмига янына, үткәне дә, сүткәне дә калмады, хәтта кайчандыр үпкә белдергән хатын-кызлар да ярдәм сорап килделәр үзенә.* Туган як. **Үткән эш** Әһәмияте югалган нәрсә турында. *Болар инде үткән эш...* Р.Зәйдулла. **Үткәндәге сүткән** *к.* **үткән дә сүткән**. *Матур гына аерылышыйк. Үткәндәге сүткән, өстенә үлән үскән.* Р.Кәрами

**Үтә бару** Бер-бер артлы үтү, һаман үтү. *Шулай бер-бер артлы еллар үтә барды.* Г.Ибраһимов. *Замана үтә бара.* Г.Исхакый. *Тормыш аны бөтерде дә алды, Авыр дулкыннары каплады, Хезмәт белән көне үтә барды, Онытылды яшьлек чаклары.* Ф.Яхин

**Үтә башлау** Үтәргә тотыну. *Эчкә салкын үтә башлагач, халык чарасын тапты: арка сугышлы уйнарга керештек һәм, чыннан да, җылындык.* А.Тимергалин. *Төрле яктан җыелган яшүсмер кала читендәге ачык кырда кылыч, сөңге орышы буенча күнекмәләр үтә башлады.* В.Имамов

**Үтә бирү** Бернигә карамый үтү. *– Җә, синең «җәһәннәм базы»ңда хәтфә келәм түшәлмәгәндер, аяк пычрак булса да үтә бирим, – дип килеп, Урмановка кулын бирде.* Г.Ибраһимов. *Үтә бирә гомер урык-сурык, Алны-ялны белми дөнья куып.* К.Булатова

**Үтә тору** Һаман, туктаусыз үтү. *Айлар, еллар үтә торды, егет күңелендәге сорауларның байтагысына җавап табылды, тик өзелеп көткән хат кына килмәде.* А.Гыйләҗев. *Ә гомер сизелмичә генә үтә торды.* В.Нуруллин

**Үтә төшү** Тагын да үтү; бераз үтү. *Бу азгын көлү йөрәгемә үтә төште.* Г.Ибраһимов. *Һәр пешкән җимеш өзеп алынырга тиеш, хәтта вакыты үтә төшсә дә.* Ф.Сафин

**Үтеп бару** Әле үтү процессында булу; акрынлап үтү. *Ләкин Ханәфи шигырьләре заманы үтеп бара шул, малай.* В.Нуруллин. *Ике ел әкрен генә үтеп бара иде.* А.Әхмәтгалиева

**Үтеп бетерү** Тулысынча үтү. *Яраланган булу сәбәпле, солдат хезмәтен үтеп бетерә алмый.* Р.Зарипов

**Үтеп бетү** Тулысынча үтү; бик нык үтү. *Ә гомерләр икән Тәмам үтеп беткән ---.* Р.Вәлиева. *Хисмәт исә, тешләрен шыгырдата-шыгырдата, бил сызлавын онытып, озын составның үтеп беткәнен көтеп, шулай кырыкка бөгелгән килеш басып торырга тиеш.* Л.Хәмидуллин

**Үтеп йөрү** Еш, һәрвакыт үтү; озак вакыт үтү. *Аралашырга өнәмәгәнен сизенгән курсташлары да аның бусагасын үтеп йөрмәделәр.* А.Гыйләҗев. *Зөләйха бер атна тирәсе эшкә урнашып, медицина комиссиясе үтеп йөрде, Лена кайтканчы, аның фатирында яшәп тордылар.* З.Хөснияр

**Үтеп китү** Тиз арада үтү. *Кызуы үтеп тә китте, ул тагын көлеп куйды.* А.Гыйләҗев. *Ике ел күз ачып йомган арада үтеп китәр, егет кайтыр, гөрләтеп туй итәрләр...* А.Әхмәтгалиева

**Үтеп тору** Бер-бер артлы, туктаусыз үтү; әледән-әле, даими үтү; әле, хәзер үтү. *Вахта артыннан вахта үтеп торды.* Г.Әпсәләмов. *Ә көннәр, поезд вагоннары кебек, бер-беренә тагылып, туктаусыз үтеп тора.* В.Нуруллин

**Үтеп яту** *сөйл. к.* **үтеп тору**. *Әмма мәдәниятта зур дәрәҗәгә ирешкән милләтләрдә хатыннар иске түбәнлекләреннән чыктылар, үзләрен ирләрдән аерган аралыкны кайсысы үрмәләп, кайсысы адымлап, кайсысы йөгереп үтеп яталар.* Г.Буби. *Менә, дустым, практика үтеп ятам.* Р.Хәбибуллина

**Үтә бару** Булган берсе үтү

**ҮТҮ** II *ф.* Яхшы кисү, үткен, кискен булу (кораллар тур.) *Нигә пычаклар үтми?* М.Яһүдин. *Ә Җиһаншин Миңлеимам абый басуда печән чапканда, иптәшләре: «Ай-һай, абый, чалгың үтә икән», – дигәннәр.* Безнең гәҗит

**Үтә башлау** Яңа гына үтә торган булу. *Менә хәзер чалгың да яхшырак үтә башлар, әүвәле тамак ялгап алыйк.* Ф.Яхин. *Чалгысы үтми башлагач, кулына кайрак алды Ильяс.* Ватаным Татарстан

**ҮТҮК** *и.* 1) Кием-салым, тукымадан тегелгән эшләнмәләрне басым астында кызу температурада тигезли торган көнкүреш техникасы. *Хәмит абзый чалбарны прилавкага китереп тә сала, ни арада кабып өлгергәндер,*

*авызыннан су бөркеп җибәрә дә әллә каян гына кайнар үтүк тартып чыгарып, чыжылдатып үтүкли дә башлый.* М.Мәһдиев. *Өйгә кергәч, теге яңа талонны кайнар үтүк белән тигезләдем дә, бик кадерләп, чәй кәгазенә төреп, кесәгә салып куйдым.* Р.Кәрами

2) *сөйл.* Чәчне ике яктан кыстырып алып тигезләү, бөдрәләрен бетерү яисә бөдрәләтү, төрле форма бирү өчен хезмәт итә торган җайланма. *Үтүк белән кератинның зыянын чагыштырсак, әлбәттә, кератин зарарсызрак.* Әлки хәбәрләре

**ҮТҮКЛӘ́Ү** *ф.* 1) Үтүк яки пар ярдәмендә тигезләү, шомарту. *Өстенә калын җәймә каплап, авызлары белән су бөрки-бөрки үтүкләгән кара сукно чалбарларының стрелкалары биш адымнан сызгырып, һава ярып торалар.* А.Хәсәнов

2) *күч.* Изеп, сытып, бомбага тотып, җир өсте белән тигезләү, юкка чыгару. *Америка очкычлары, козгыннар өере шикелле, дистәләп-йөзәрләп килеп, япон мәркәзенең исән калган йортларын үтүклиләр.* В.Имамов. *Әйтерсең лә бомбага тотканнар үзләрен, танклар белән үтүкләгәннәр.* Д.Гыйсметдин

**Үтүкләп алу** Тиз генә үтүкләү. *Иртәгә яңа эшкә чыгасы дигән көнне бердәнбер костюмын тагын бер кат чистартып, үтүкләп алды.* Р.Мирхәйдәров. *Онытып җибәргәнмен бит: кичә юган керләрне үтүкләп алыйм дигән идем, вакытның узганын да сизмәгәнмен, дигән булды.* Г.Галиева

**Үтүкләп ату** Тиз-тиз генә, аннан-моннан үтүкләү

**Үтүкләп бетерү** Тулысынча үтүкләү; барысын да үтүкләү. – *Илсөя үтүкләп бетермәгән керләрен берәм-берәм диванга томырды да, күз яшьләренә буылып, кухняга чыгып китте.* А.Әхмәтгалиева. *Үләм дип торам, үтүкләп бетерә яздым, илһам килми генә бит!* Н.Кәримова

**Үтүкләп җибәрү** Бераз, җиңелчә үтүкләү. *Киемнәрне киптереп, үтүкләп җибәргәч, аның кәефе күтәрелеп китте.* Ф.Яруллин. *Киләсе сезонда тартмасыннан чыгаргач, бөгәрләнгән кырларын үтүкләп җибәрергә була.* Сөембикә

**Үтүкләп йөрү** Әле үтүкләү. *Әнисе, Сәрвәр ханым, керләр үтүкләп йөри иде.* А.Гыйләҗев

**Үтүкләп кую** Алдан үтүкләү. *Син аларны бер арада чайкап та, үтүкләп тә куярсың инде.* А.Гыйләҗев. *[Мөнирҗан] Чалбарын үтүкләп куйды, пинҗәгенә булган орден-медальләрен җентекләп беркетте.* Н.Әхмәдиев

**Үтүкләп тору** Гел, һәрвакыт үтүкләү; әле, хәзер үтүкләү. *Вахит барып кергәндә, Гаделнең анасы керләр үтүкләп тора иде.* Г.Гыйльманов. *Шулай булгач, син аны гел үтүкләп кенә тор инде.* З.Мәхмүди

**Үтүкләп чыгу** Һәрберсен берәм-берәм үтүкләү; тулысынча үтүкләү. *Күп тә калмаган. Егерме бишмәткә җиң утыртасы да төймә тагасы. Аннан азмаз үтүкләп чыгасы.* Г.Ибраһимов. *Көчсез булсаң, илеңне танклар белән үтәдән-үтә үтүкләп чыгарлар...* Ш.Галиев

**Үтүкли бару** Һәммәсен бер-бер артлы үтүкләү. *Кипкән бер керне үтүкли бардым*

**Үтүкли башлау** Үтүкләргә тотыну. *Гимнастёрка белән чалбарымны да киез астына җәеп үтүкли башладым...* И.Салахов. *Хәмит абзый чалбарны прилавкага китереп тә сала, ни арада кабып өлгергәндер, авызыннан су бөркеп җибәрә дә әллә каян гына кайнар үтүк тартып чыгарып, чыжылдатып, үтүкли дә башлый.* М.Мәһдиев

**Үтүкли тору** Әлегә үтүкләү. *Сез менә бу төшен үтүкли торсагыз да була...* М.Маликова

**ҮТҮТ** *хәб. сүз.* Берәр нәрсәнең китүен, бетүен, узуын, була алмавын белдерә. *Янарал дип дерелдәп торулар үтүт инде.* Г.Бәширов. *Үтүт матай, кулдан ычкына матай!* Н.Гыйматдинова

**ҮЧ** *и.* **1.** Кайчандыр җәберләгәне, кыерсытканы өчен берәүгә булган ачу, ачулы ният, аңа карата эшләнгән явыз эш. *Мин усал күңелле кара эчле хатынга әйләндем, һәр бәхетле кешегә үчем бар иде минем, ачуым!* А.Гыйләҗев. *Шушында сурәтләнгән Изге Мария сине ялгыш адымнардан, кызулыктан, дошманнарың үченнән сакласын.* В.Имамов

**2.** *хәб. функ.* 1) *сөйл.* Берәр нәрсәгә бик һәвәс, оста булу сыйфаты. *Убыр яңа туган баланы алмаштырып китәргә бик үч була.* Ф.Урманче

2) Берәр нәрсәне бик нык ярату сыйфаты. *Кәҗә кәбестәгә үч икән*

3) Ачулы, үпкәле. *Үз-үзеңә син үч икән, Биргәнсең кирәгеңне!* М.Җәлил

◊ **Үч алу** Явызлыкка җавап итеп явызлык эшләү. *Бу ике кешедән, ничек кенә, кайда гына туры килмәсен, үч алырга уйлады ул.* А.Алиш. *Дошманнарына аннан канлы үч алырга җай чыга.* А.Хәсәнов. **Үч итеп** 1) Ачудан; усаллыкка җавап итеп. *Минем ният, хәлфәнең бу сәбәпсез җәзалавына үч итеп, өйгә кайтып китү иде.* Г.Бәширов. *Берәрсе миңа үч итеп эшләгән эш икәнлеге көн кебек ачык иде.* В.Нуруллин; 2) Бирешмичә, көч-ихтыяр күрсәтеп. – *Син нәрсә, кызлар өчен акылы булган кеше элмәккә үреләме? Үч итеп яшәргә кирәк!* А.Хәйретдинова. **Үч иткәндәй** Тыгыз, авыр вакытта, көтмәгәндә, эшне тиз генә башкарырга теләгәндә, бәрәр каршылык, уңышсызлык килеп чыгу турында әйтелә. *Башкалар киттеләр, үч иткәндәй, Вәсимә калды.* А.Алиш. *Үч иткәндәй, бүген бу урамда багана утлары да янмый иде.* А.Гыймадиев. **Үч иткән кебек** *к.* **үч иткәндәй**. *Үч иткән кебек, [ай] тулы йөзе белән болыт астыннан чыгып, миңа ике тапкыр карады.* Г.Ибраһимов. **Үч иткән шикелле** *к.* **үч иткәндәй**. *Иптәш малайлар, үч иткән шикелле, нигәдер гел безнең бабайлар өе тирәсендә уйныйлар.* В.Нуруллин. **Үч иткән сыман** *к.* **үч иткәндәй**. **Үч йөртү** *к.* **үч саклау**. *Кара җаннар Үч йөрттеләр, Төнлә өйгә Ут төрттеләр.* И.Юзеев. *Шунысы кызык: ул нишләптер Айсинга кинә сакламады, үч тә йөртмәде.* А.Хәлим. **Үч кайтару** *к.* **үч алу**. *Ярый, без моның үчен кайтарырбыз.* А.Вергазов. *Бәлки... бәлки, миңа атай өчен үч кайтарырга җай чыгадыр?..* В.Имамов. **Үч кайту** *к.* **үч кану**. – *Үч кайтты әзрәк. Сулыш алулары да җиңеләйде кебек, – диде ул Андрей Борзенковка.* Г.Әпсәләмов. – *Син шул кызың өчен үч алдың... Я, үчең кайттымы соң?* Н.Акмал. **Үч кану** Үч алып канәгатьләнү, үч алганнан соң, әлеге теләк бетү. *Мин сорыйм синнән хәзер: үтереп үч кандымы?* М.Мәһдиев. *Әмма эзләүдән канәгатьләнү, үч кану дигәннең эзе дә күренми.* У.Шекспир. **Үч саклау** Үч алу ниятен онытмау, һәрдаим үч алу җаен көтеп, сагалап йөрү. *Шул эшләр аркасында аның күп дуслары рәтеннән каты үч саклаган дошманнары да туды.* Г.Ибраһимов. *Майяны әйтәм, бер дә үч сакламаган, киткән тагы...* Г.Гыйльманов. **Үч тоту** *к.* **үч саклау**. *Кирәк чакта ут йотыгыз – үч тотмагыз ---.* Р.Әхмәтҗанов. *Моңсыз кешегә үпкәли дә, үч тә тота алмый.* А.Хәлим

**ҮЧЕГЕП** *рәв.* Ярсып, ярсынып; котырып, котырынып. *Тез тиңентен су шәрә балтырларны өшетә, тирләгән аркаларны суык җил үчегеп кыйный иде.* А.Гыйләҗев

**ҮЧЕГҮ** *ф.* 1) Ачу саклау, үч йөртү. *Кемгә үчексәң, шул дошман.* Мәкаль. *Идрис, Мөхәммәтшинга үчегеп, атлар яндырды.* Н.Гыйматдинова

2) Ачулану, үпкәләү. – *Син миңа үчекмә, – диде Рәфис, Шәмсуннең килеш-килбәтеннән ни уйлаганын чамалап, – үзеңә файдага әйтәм...* А.Вергазов. *Миңнеханга үчегеп, чит җирләрдә сукбайлыкта йөрергә җитте сиңа, туган.* В.Имамов

3) Каныгу, ябышу, бәйләнү. *Беркем сиңа үчекми. Барысы да сине яратып торалар.* А.Гыйләҗев. *Канлы көрәш эчендә Үлемнән качуы җиңел, Ул куркакка үчегә.* Р.Зәйдулла

**Үчегеп йөрү** Озак вакыт үчегү; әле, хәзер үчегү. *Завхозлыктан төшергәннәр аны, шуңа үчегеп йөри.* А.Гыйләҗев. *Шулай уйласам да, көне буе үземә дә, Әминәгә дә үчегеп йөрдем, һәр алган бишлесе эчемне пошырды.* Л.Гыймадиева

**ҮЧЕГҮЧӘН** *с.* Тиз яки еш үчегә торган; каныгучан. *Үчегүчән кеше*

**ҮЧЕГҮЧӘНЛЕК** *и.* Үчегүчән булу сыйфаты

**ҮЧЕКЛӘ́Ү** *ф.* Юри ачуны китерү, ярсыту, үртәү. *Кайчакта иректә йөри торган урам этләре, бу ишегалдына кереп, бу этне котырталар вә үчекләр иде.* Г.Тукай. *Ә чык бөртекләре чәчелеп китәләр дә кабат үлән яфракларына, камылларга килеп куналар, я булмаса Хәбирнең сандалиена тулып, аны үзләренчә үчекләр иде.* Г.Гыйльманов // Кемне дә булса мыскыллап, күңеленә тимәкче булып яки ачуын китерү нияте белән сүзләрне бозып, ямьсезләтеп яисә кабатлап әйтү, йөзне ямьсезләтеп күрсәтү, ямьсез кылану. – *Мин, мин... – дип үчекләде аны Гөлфинур, иреннәрен аяусыз бөрештереп.* А.Вергазов // Хәтер калырлык кушамат әйтү. *Шуннан соң Зәки абый «концерт» биргән чакларда, бүтән малайлар аны «Кашшыбутерсен» дип үчекләгәндә, мин ерактан гына карый торган булдым.* В.Нуруллин. *Мәктәптә укыганда, үчекләп, Шариков Тузик дип йөриләр иде.* Аманулла

**Үчекләп алу** Берара, бераз гына үчекләү. *Ишек ябылганда, телен чыгарып, малайны тагын бер кат үчекләп алды.* Н.Акмал. *Мин дә югалып калмадым, телемне чыгарып үчекләп алдым.* И.Диндаров

**Үчекләп йөрү** Гел, озак вакытлар үчекләү. *Койрыгын борган кәҗә бәтие кебек: «ә-ә-ә-ә», «мә-ә-ә» кычкырмагыз, дип үчекләп йөрде үзләрен.* Г.Әпсәләмов. *Элегрәк Хәлил абзый аны: «Мәхәббәт гәҗите укыр көнгә калдыңмыни, кортка!» – дип үчекләп тә йөргән иде.* З.Хөснияр

**Үчекләп килү** Әлегә кадәр үчекләү. – *Дилбәр – кызлар исеме ул! – дип үчекләп килдем.* Р.Нуруллин

**Үчекләп кую** Көтмәгәндә үчекләү. *Һәдияне кайчакта Рөстәм Шакирович «Ярка хәтле весың юк!» дип үчекләп куя.* М.Әхмәтшина

**Үчекләп тору** Даими үчекләү; әле, хәзер үчекләү. *Әйтеп тә бетерә алмадым, әле генә шыгырдап, үчекләп торган итекләрнең берсе очы белән тез астыма батып керде.* И.Салахов. *Аның чыгырдан чыгарасы килә, минем тын ятуыма тагын да ныграк үртәлә, күрәмсең, бертуктаусыз үчекләп тора.* Ф.Баттал

**Үчекли башлау** Үчекләргә тотыну. *Куян малае аптырап тормаган, телен чыгарып, Төлкене үчекли башлаган.* Г.Гыйльманов. *Класс, шаулашып-гөрләшеп, Наятьне үчекли башлады ---.* Н.Акмал

**Үчекли килү** *к.* **үчекләп килү**

**Үчекли тору** Озак, өсте-өстенә үчекләү. *Төрле яктан үзен эткәлитөрткәли торгач, кыстый, үчекли торгач, Мансур түзмәде, ни булса булыр дигәндәй, кулын селтәде ---.* Н.Фәттах

**Үчекли төшү** Бераз үчекләү; тагын да ныграк үчекләү. *Шунда Мансур, Илмираның үзенә карап торуын сизеп алып, башын аңа таба борды: кыз үчекли төшеп елмайган: «Шүрлисең икән, егет», – дип әйтә иде кебек аның бу шаян күз карашы.* Г.Әпсәләмов

**ҮЧЕКТЕРҮ** *ф. к.* **үчекләү**. *Чатанның да Газинур абыйсын бераз үчектерәсе килде ---.* А.Хәсәнов. *Сүз көрәштерү икесен дә ярсытты, үртәде, үчектерде генә.* Ә.Сәйфетдинов

**Үчектерә төшү** *к.* **үчекли төшү**. *Бу җавап Мусаны тагын да үчектерә төште.* Ш.Маннур

**ҮЧЕРГЕЧ** *и. бот. к.* **шомбия**

**ҮЧЕРҮ** *ф. диал.* Бетерү, юкка чыгару; юк итү. *Авылдагы этләрнең нәселен үчерде ул: умарта каравылчысы Хафиз карттан мылтык алып торып, сигез этнең сигезен дә үз кулы белән атып үтерде.* В.Нуруллин. *Зыятдин станциясендә бераз черем итү килешкәнме, алдагы бәхетсезлек тынычлыгын үчердеме – үзе дә белмәде.* Т.Әйди

**ҮЧЛӘНҮ** *ф. к.* **үчегү**. *Ындыр тулы иске кибәннәребез утырса, без дә үчләнмәс идек!* М.Галәү. *Нефтьчеләргә болай да сагаеп караган халык хәзер аларны каһәрләде, үчләнде.* Ф.Яруллин. *Нигә, нәрсә өчен миңа шулай үчләнәләр соң, ә, Ак бабай?* Г.Гыйльманов

**Үчләнеп йөрү** *к.* **үчегеп йөрү**. *Заводта, компьютерда эшләмәгән өчен, баш механик Закиров миңа күпме үчләнеп йөрде, премияләрдән коры калдырды.* Н.Хәсәнов. *Гафур кемнәрдер аркасында авырлыклар кичерде, ләкин үпкә саклап, үчләнеп йөрмәде.* Безнең гәҗит

**Үчләнеп китү** Кинәт үчләнү. *Әмма ничек кенә булмасын, аңарчы да бик үк тату булмаган монголлар белән татарлар шушы хәлләрдән соң бер-берено тагын да ныграк үчләнеп китәләр.* Р.Фәхретдинов

**ҮЧЛӘШТЕРҮ** *ф.* Кешеләрне берберсенә үчле итү, бер-берсенә каршы котырту, араларын бозу. *Ялан бия ике айгырны үчләштерер.* Мәкаль. *Шунысын онытма: затлы мал дошман җанына вәсвәсә сала, үчләштерә, көнләштерә, нәфесен котырта.* Ф.Латыйфи

**Үчләштереп бетерү** Бик нык үчләштерү; барысын да үчләштерү

**Үчләштереп йөрү** *к.* **үчләштереп тору**

**Үчләштереп кую** Көтмәгәндә үчләштерү

**Үчләштереп тору** Әледән-әле, даими үчләштерү; әле, хәзер үчләштерү

**ҮЧЛӘШҮ** *ф.* Бер-береңә үчле булып китү, үч саклау. *Бер-беребезне алдадык, үчләштек, дошманга саттык.* Р.Зәйдулла. *Электән, күптән килгән танышлыклары дәвамында үчләшкән чаклары да бар иде аларның, ә мондый кайгылы вакытында алай ярамый.* Ф.Яхин

2) Берәүгә үчлек эшләү; үч итеп, явызлык кылу. *Кем өчен үчләшә алайса?* А.Гыйләҗев. *«Эзләп тапкан, эте өчен үчләшергә килгән...» дигән уй аны йокыдан тәмам айнытып җибәрде, һәм ул моның төш түгеллегенә ышанды.* Н.Акмал

**Үчләшә башлау** Үчләшергә тотыну. *Ә берзаманны Җантуринда да шуның төсле мыек күреп алгач, үчләшә башлаган инде бу.* В.Имамов. *Үчләшә башласаң, Майяга таш орган бәндәләр Нәфисәгә дә кул күтәрмәс дип кем әйтә ала?* Г.Гыйльманов

**Үчләшеп йөрү** Берникадәр вакыт үчләшү. *Мирзәкәй миңа үчләшеп тә йөргән ие әле ул җылны.* Л.Лерон

**Үчләшеп тору** Даими үчләшү; әле, хәзер үчләшү

**Үчләшеп утыру** *сөйл. к.* **үчләшеп тору**. *Алты ел элек бер тапкыр суккан-га үчләшеп утырмасаң...* А.Фәләх

**ҮЧЛЕ** *с.* Үч саклап йөрүче; үчегүчән. *Безнең халык бит үчле түгел.* А.Хәсәнов. «*Кыйналып үскән бала дөньяга үчле була ул, әнисе», – ди торган ие, мәрхүмкәем.* А.Әхмәтгалиева

**ҮЧЛЕК** *и.* Явызлык, усаллык. *Карьерамны бозып куяр үчлек белән, Нигә миңа вакланырга бу чүп белән!* Г.Афзал. *Ил-йортыгыз үчлектән җимерелгән, яңа нигезегез ялганнан корылган.* Ф.Сафин. *Ә инде ул сиңа үчлек белән синең якыннарыңа, син җитәкли торган коллектив кешеләренә дә явызлык эшли башласа – хәлләр яман.* В.Нуруллин

◊ **Үчлек тоту** Үч саклау, начар мөнәсәбәттә булу. *Хикмәт хаҗи кешесе бу гаиләгә үчлек тота, йорт хуҗасына төрле ялалар яга.* Х.Миңнегулов

**ҮЧЛЕ́К ИТҮ** *ф.* Явызлык кылу, усаллык эшләү. *Син бит минә сазлык пычрагыдай Сөйрәләсең, үчлек иткәндәй.* М.Җәлил

**ҮЧЛЕ́К КЫЛУ** *ф. к.* **үчлек итү**. *Ә син миңа – ярымдыр, апам шуны телидер, җанга булсаң җанашым, апам үчлек кылмыйдыр!* Ф.Яхин

**ҮЧЛЕКЛЕ** *с.* 1) *к.* **үчле**. *Шул кыртәне узмаган егет-малай явыз, кешегә каныгучан, үчлекле була.* М.Мәһдиев

2) Усал, усаллыкны, үчле булуны чагылдырган. *– Канәгатьме, дим, Йосыф морза? – диде Исмәгыйль, аның күзендә зәһәр бер үчлекле елмаю чагылып узды.* Р.Батулла. *– Беләм мин сине... – диде Сәгыйтов чыгып барышлый үчлекле тавыш белән.* Ф.Сафин

**ҮЧЛЕЛЕК** *и.* Үчле булу сыйфаты; үчегүчәнлек. *Гаҗәп чикләнгәнлек, үчлелек, фикерләү кытлыгы каян килгән бу кешегә?* Г.Тавлин. *Шулхәтле үчлелек, ярсу белән әйтә ул боларны, Газзә гаҗәпләнеп кала.* М.Маликова

**ҮЧТЕКИ** *ы.* **1.** Нарасый баланы учта сикертеп уйнатканда әйтелә. *Әнисе тыштан кергән арада, эмоцияләргә бирелә: – И-и-и сеңлем, яратам бит мин сине! Үчтеки, үчтеки! – дип, фланельгә төргән баланы түшәмгә чөеп уйный.* М.Мәһдиев

**2.** *и. мәгъ.* 1) Нарасый баланы үчтеки әйтеп, такмаклап, учта сикертү, ярату уены. *Йа Хода, кичә генә тез башында үчтеки уйнаган сабый тәмам егет булып килә ләбаса!* А.Әхмәтгалиева

2) Такмаклап, баланы иркәләү, ярату. *Яшь әниләргә ярдәм йөзеннән үчтекиләрне барлап, бер җиргә тупларга булдык.* Сөембикә

**ҮЧТЕКИ́ ИТҮ** *ф. к.* **үчтекиләү**. *Ул әле баланы үчтеки итте – сикертте, әле бит алмаларыннан убә-убә сөйде, әле елар чиккә җиткән баланы юатырга керешә.* М.Хәбибуллин

**ҮЧТЕКИЛӘ́Ү** *ф.* 1) Үчтеки әйтеп сикертү. *Уяу ятса, карашын гел әнисеннән алмый, «ыгы-ыгы» дигән аваз чыгарып көлгән я тибенгән була, кулга алмыйча, үчтекиләп сөймичә калулары читен.* В.Имамов. *Суга сусаган кеше кебек, шул баланы кочагына алып, сабый исен исни-исни, рәхәтләнеп сөясе, иркәлисе, үчтекилисе килде!* Р.Хәбибуллина

2) *күч.* Бик кадерләү, артык иркәләү. *Аннары китереп, әдипләрне массакүләм җитештереп булмый, ул, кем әйтмешли,данәле товар, аны берәмтекләп кенә үстерергә ярый, ләкин үчтекиләп түгел!* А.Тимергалин

**Үчтекили башлау** Үчтекиләргә тотыну. *Һәм баланы, аның кулыннан алып, тезенә утыртты да үчтекили башлады.* М.Маликова

**ҮЧТИ́-ҮЧТИ** *ы. к.* **үчтеки**. *Үчтиүчти, Үчти-үчти үчтеки, үсте китте кечтеки. Үсте, үсте – зур булды ---.* Р.Харис

**ҮЧҮ** *ф. диал.* 1) Юкка чыгу, бетү, үлү. *Шулай булгач, ничек үчмәсен ул авыл?* В.Нуруллин

2) Бөлгенлеккә төшү, хәерчеләнү

3) Сүнү, сүнеп бетү

**Үчеп бару** Акрынлап үчү. *Горефгадәтләре дә үчеп бара. Ә боларны тыңласаң – чәчәк атабыз, яхшы яшибез.* В.Шугаев

**Үчеп бетү** Тәмам үчү. *Монда хәлләр бөтенләй башка. Бигрәк тә хәзер, иске үчеп бетмәгән, яңа тамыр җибәрергә өлгермәгән, сыйнфый дошманнар безгә – Рәсәйдән килүчеләргә карата ышанмаучылык уятырга тырышкан көннәрдә.* Т.Әйди

**ҮШӘН** *с.* **1.** 1) Ялкау, тыңламый, киреләнә торган; сүлпән (җигелә торган хайван тур.). *Ә синең коммуныңа кергән чакта, Рамай да сабан-тырма салган бер ат җигеп килде, Харис та шул ике суксаң бер атламый торган үшән алашасын җитәкләп килде.* В.Имамов. *Камытны аны үшән атлар гына кия. Ә мин – канатлы ат!* Л.Лерон

2) Иренчәк; әкрен. *Бер патшаның өч кызы булган. Икесе бик тә уңган, тиктормас, өченчесе үшән, ялкау, йокы чүлмәге булган, ди.* Р.Батулла. *Кышкы йокыдан айный алмыйча, иңке-миңке йөргән үшән кала халкын капыл яз бик тиз аякка бастырды.* М.Әмирханов

3) *күч.* Акрын, сүлпән бара торган. *Гадәттән тыш хәл юк шикелле, күбебез үшән, ваемсыз, томана тормыш белән яшәп ята бирәбез.* Г.Ахунов

**2.** *рәв. мәгъ.* Ялкауланып, иренеп кенә; тыңламыйча; киреләнеп. *Мин җирдән таза гына чыбык алдым да үшән генә басып торган алашаның җилкәсенә сыдырдым.* А.Гыйләҗев

**3.** *и. мәгъ.* Ялкау, иренчәк кеше; әкрен кеше. *Ил эченә сыйдырамы иләт Иләмсезне, гамьсез, үшәннәрне.* Ф.Гыйззәтуллина. *Синең кебек үшәннәргә генә эш юк ул, ата ялкау.* К.Кара

**ҮШӘНЛӘНҮ** *ф.* Үшәнгә әйләнү. *Үз көенә чабып барган ат та, үшәнләнеп, адымлауга күчте.* Н.Хәсәнов. *Битараф без: үшәнләнгән, Үтмәсләнгән, өшәнгән...* Л.Шагыйрьҗан

**Үшәнләнә башлау** Үшәнләнергә тотыну. *Күчтәннән чыгып, Ирәндеккә җитәр-җитмәстән, ат үшәнләнә башлады.* Т.Гарипова

**Үшәнләнеп бетү** Тәмам үшәнләнү. *Кулындагы куянның шактый ук батыр һәм йөгерек куян икәнен белгән хәлдә, без, укучылар, күңелдәге арысланның дөньяга чыгуыннан да өмет өзмибез, тик ул арыслан күңел читлегендә озак ятып, зоопарк баһадиры сыман үшәнләнеп бетмәсен иде дигән теләктә генә калабыз.* Р.Вәлиев. *Янгын сүндерүчеләр күптәннән эшсез ятып үшәнләнеп беткән атларын урыннарыннан кузгата алмый, кузгаткач, тәртә арасына кертә алмый азапландылар ---.* Д.Каюмова

**Үшәнләнеп калу** Нәрсәнеңдер ахырында үшәнләнү. *Аргамагым тагын уйнап китәр Иде юллар буйлап, ямь биреп... Әмма атым үшәнләнеп калды, Күңелем дә инде җимерек.* Ф. Яхин

**Үшәнләнеп тору** Әле, хәзер үшәнләнү. *Күктә кояш, тышауланган кебек, гел бер урында үшәнләнеп тора, урман артына тәгәрәп төшәргә һич тә ашыкмый.* М.Галиев

**ҮШӘНЛЕК** *и.* Үшән булу сыйфаты. *Ашыгу – ахмаклык, кичегү – үшәнлек.* Мәкаль. *Сәгыйдә мондый җавапка сөенгәндер дисезме? Киресенчә, мине үшәнлектә гаепләде.* Ә.Маликов

# Ф

**ФА** *и. лат. муз.* 1) Музыкаль гамманың «ми»дән соң килгән дүртенче авазы. *Көйнең башындагыча, секунд аралары буйлап югары күтәрелә – «ре», «ми», «фа» – «Рау-ша-ни-ям».* М.Мәһдиев. *Яңадан клавишларга каты гына суга башладым: до, ре, ми, фа, соль... Менә шулай, авазлардан гамма хасил була.* Ә.Еники

2) Шул авазны билгели торган нота

**ФАБЗАВКОМ** *и. рус тар.* Фабрика-завод комитеты. *Фабзавком үзенең сумаларына әлбәттә учёт ясый торгандыр.* Г.Камал. *Фабзавкомда, икътисади киңәшмә җыелышында, дип җавап бирделәр.* Г.Ибраһимов

**ФАБЗАВУЧ** *и. рус тар.* Предприятие (аерым кәсәбә) карамагындагы фабрика-завод училищесы. *Нәкъ 25 нче елның көзендә мин аны Мәскәүдәге фабзавучка биреп калдырган идем.* Ш.Усманов. *Фабзавучта һөнәр үзләштерү*

**ФАБКОМ** *и. рус тар.* 1) Фабриканың профсоюз комитеты. *Партком белән фабком теш-тырнак белән каршы торган чагында, миңа берүземә мәсьәләне чишү кыенрак шул.* Ш.Камал. *– Ике китек язмыш бер булсын, өйләнешик булмаса, – дигәч тә, фабком рәисе Динә ханым янына киңәшкә йөгерә Нажия.* Р.Камалетдинова

2) *сөйл.* Фабриканың профсоюз комитеты рәисе. *Фабкомның әйтүенә караганда, сез миңа, премия итеп, автомобиль алып бирү турында сөйләшкәнсез икән.* Ш.Камал

**ФА́БРА** *и. нем. иск.* Чәч, сакал һәм мыекны кара төскә буйый торган буяу

**ФА́БРИК** *и. сөйл. к.* **фабрика**. *Мускулларның көчен сыгып тапкан миллионнардан яңа фабрик салдык.* Х.Госман. *Әмма хәзер кырыктартмачылык белән ерак китеп булмый. Безгә милләтебезнең завод, фабрик тотучылары күбрәк кирәк.* Т.Миңнуллин

**ФА́БРИКА** *и. лат.* Чимал эшкәртеп, продукция җитештерә торган җиңел сәнәгать предприятиесе. *Мостафа абый үзе елның күп вакытында шәһәрдән алтмыш чакрым ераклыктагы сукно фабрикасында тора.* Ф.Әмирхан. *Фарфор фабрикасыннан күтәрелгән актив хәбәрче.* М.Җәлил

**ФАБРИКА-ЗАВОД** *җый. и. рус* Чимал эшкәртеп, яңа продукция җитештерүгә нигезләнгән, күпсанлы эшче көчләр туплаган эре сәнәгать предприятиеләре. *Хәзер инде алар фабрика-завод хуҗалары белән бөтенләй башкача, аяк терәп сөйләшәләр.* К.Нәҗми. *Монда [Бөекбританиядә] эре фабрика-завод промышленносте башка илләрдәгедән элегрәк барлыкка килгән.* Чит илләрнең экономик географиясе

**ФАБРИКА-КУ́ХНЯ** *и. рус* Ашамлык әйберләрен күпләп җитештерә торган җәмәгать туклануы предприятиесе

**ФАБРИКАНТ** *и. лат.* Фабрика хуҗасы. *Мәскәү байлары һәм фабрикантлары товарны көтәргә сатарга бер дә курыкмыйлар.* Ш.Мөхәммәдев. *Галкәй хаҗида управляющий булып хезмәт иткән немецның төпчек улы – яшь фабрикант Арнольд Эгерс иде.* К.Нәҗми

**ФАБРИКАТ** *и. лат.* Эшкәртеп чыгарылган әзер продукт. *Фабрикат җитештерү*

**ФАБРИКА́ЦИЯЛӘҮ** *ф. лат.* Гаепләү өчен чынбарлыкны бозып күрсәткән документлар әзерләү, дөреслеккә туры килмәгән уйдырмалар чыгару, ялган шаһитлардан файдалану. *Төрле имеш-мимешләрдән җыеп фабрикацияләү*

**Фабрикацияләп кую** Алдан әзерләп фабрикацияләү

**ФА́БУЛА** *и. лат. әд.* Әдәби әсәрнең эчтәлеге, сюжет үсеше, андагы вакыйгаларның эзлекле сурәтләнеше. *Г.Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романы «Фәхрине үтереп ташладылар» дигән атаклы җөмлә белән башланып китә дә, фабула җебе шуңа бәйле рәвештә сүтелә, үстерелә...* Т.Галиуллин. *Чехов, Ш.Камал хикәяләре искә төшә. Сөйләм эзлекле фабула канвасы буенча бара.* Казан утлары

**ФАВОРИТ** *и. фр.* 1) Абруйлы, зур йогынтылы кешенең химаясеннән файдаланып, ярдәм алып яшәүче, аның тарафыннан яклanучы кеше. *Өйләнгән иптәшләре гыйлем дөньясында фаворитлар тудыралар.* М.Мәһдиев. *Пьедесталга әнә шулай күтәрелә фаворит, башкаларга караганда күпкә азрак эшләп тә...* З.Мансур

2) Югары дәрәҗәле затның сөяркәсе. --- *бу вакытта Анна Иоанновна, авырып, түшәктә яткан була. Офицер шундук патшабикәнең фавориты Биронга хәбәр итә.* М.Кәбиров. *Екатерина II фаворитлары*

3) Үзенең осталыгы, булдыклылыгы белән башкалардан өстен булып күренгән, яхшырак дип саналган, яраткан кеше. *Бу актёр – тамашачыларның фавориты*

4) *спорт* Беренчелекне дәгъвалый алырлык спорт төре, спортчы яки ат. *Оста жокей фаворит булмаган юртакны да беренче алып килергә мөмкин.* Ялкын. *Спорт державасы саналган ил хәтта фаворит саналган уен төрләрендә дә (хоккей, фигуралы шуу, чаңгы) җиңелүгә дучар булды.* Кәеф ничек?

**ФА́ВУС** *и. лат. мед.* Башның чәчле өлешен, сирәк очракларда тырнаклар, эчке әгъзалар зарарлануга китерә торган гөмбә авыруы

**ФАГОТ** *и. ит. муз.* Түбән тембрлы, күп клапанлы, киңәебрәк киткән озынча көпшә рәвешендәге тынлы музыка коралы. *Бакчага сыенып утырган музыка мәктәбеннән флейта, фагот, тагын берничә музыка коралы кычкырткан, пианинода уйнаган авазлар ишетелеп, зиһенне чуалта иде.* Г.Бәширов

**ФАГОТЧЫ** *и.* Фаготта уйнаучы музыкант. *Җ.К. Айдаров та, хәрби оркестрдагы хезмәттәшләре В.М. Орловский (тромбончы), П.К. Орехов (валторначы) һәм Г.З. Еремкин (фаготчы) белән бергә, командировка кәгазе алып, «Радиокомитет башлыгы карамагына» күчәләр.* Фәнни Татарстан

**ФАГОЦИТ** *и. лат. мед.* Организмга үтеп кергән микроорганизмнарны, ят кисәкчекләрне һәм таркалган күзәнәкләрне эләктереп ала, йота, эшкәртә ала торган хәрәкәтчән күзәнәкләрнең гомуми атамасы. *Лейкоцит яшь чакта үзенең кем буласын хәл итәргә тиеш. Кирәк булса, ул фагоцитка әверелә ала*

*һәм микробларга каршы сугышка китә.* Кызыклы физиология

**ФАГОЦИТОЗ** *и. лат. мед.* Фагоцитларның микроорганизмнарны, ят кисәкчекләрне, таркалган күзәнәкләрне актив йоту һәм эшкәртү процессы. *Иммунитет факторларында, фагоцитоз һәм кандагы лимфоцитлар санында шулай ук тәүлеклек ритмнар чагылыш табалар.* Р.Гыйльметдинова

**ФАГЫЙЛИЯТ** *и. гар. иск.* 1) Эшчәнлек, эшлеклелек

2) Эшнең тәэсир итү көче; эшләгән эшнең мәгънәсе

**ФАГЫЙЛЬ** *и. гар. иск.* Эшләүче, башкаручы, кылучы. *Голүме иҗтимагыя галимнәре, адәмнәре үзләре тарихта фагыйль була алалар.* Г.Гобәйдуллин. *Тешләү белән күзләүнең һәр икесендә теш һәм күз белән бер эш эшләү аңлашыла, ягъни теш белән күз фагыйль була.* Җ.Вәлиди

**ФАҖИГА** *и. гар.* 1) Аянычлы хәл, коточкыч вакыйга, һәлакәт. *Көн уртасында үзләре белән тирән фаҗига – Рәүфнең үле гәүдәсен алып кайтып кerdeләр.* Г.Минский. *Ул сиңа шушы сугышка, шушы фаҗигаларга, үлемнәргә үч итеп яшәргә кушты...* Г.Гыйльманов

2) Зур кайгы, бәхетсезлек. *Яшерен шагыйрь Кәрим Мәхдүм белән Госман бу көннәрдә үзләрен бик авыру вә бөтенләй эчке фаҗига тәэсирендә кебек хис иттеләр.* Г.Ибраһимов. *Утә дә якын, җир йөзендәге берни белән дә чагыштырмаслык шушы изге исемне ике мәртәбә кабатлаганда, аның кичергән барлык фаҗигасы, йөрәгенә кара кан булып урнашкан мәңгелек кайгысы кешеләрне тетрәтте.* Ф.Садриев

**ФАҖИГАЛЫ** *с.* **1.** 1) Төрле һәлакәт, бәла-казалардан торган, шуның нәтиҗәсендә килеп чыккан. *Көрәш һәм батырлык темасы Рәйханәнең кызганыч язмышы, фаҗигалы үлеме мотивлары белән аралашып бара.* М.Җәлил. *Бу фаҗигалы сугыш аркасында күргән барлык хәсрәтләребез онытылыр.* Р.Ишморат

2) Авыр кичерешләрдән, тирән борчу-хәсрәттән торган. *Фаҗигалы минут һәм секундлар уза.* М.Җәлил

3) Аһәңендә, тавышында фаҗига булуын белдергән. *Алар концерттан үзләре белән бергә киткән өч кызны күмәк булып өйләренә озатып йөргән чагында, --- әлеге фаҗигалы тавышны ишеттеләр һәм, Фәридә белән Гөлбануны шунда калдырып, --- тавыш килгән якка йөгерделәр.* Ш.Камал. *Ә эшелонны фаҗигалы музыка озатып калды...* К.Латыйп

**2.** *рәв. мәгъ.* Һәлакәтләр белән тулы, хәвефле, казалы булып. *Сәлим --- Казан институтларының берсенә кереп укый башлады, ләкин аның язмышы артык фаҗигалы булып бетте.* А.Расих

**ФАҖИГАЛЫЛЫК** *и.* Фаҗигалы булу. *Туйның үзенә бәйләнешле кыз елату җырларының, сыктауларның эчтәлеген билгели торган төп сыйфат – трагизм, фаҗигалылык.* М.Бакиров. *Мифтан һәм мифологик хикәятләрдән аермалы буларак, әкиятләрдә фаҗигалылык бөтенләй юкка чыга.* Ф.Урманче

**ФАҖИГАСЫЗ** *с.* Төрле бәла-казалар, һәлакәтләр китереп чыгармаган, фаҗигаларга юл куймаган. --- *болгарларның кушылуы һәр ике як өчен дә фаҗигасыз процесс булган.* Ә.Кәримуллин

**ФАҖИГЫЙ** *с. гар. к.* **фаҗигалы**. *Сезгә мин җырламыйм, сезгә башкорт булып туудан башка гөнаһысы булмаган фаҗигый язмышлы Гөлбикә моңлана ---, диясем килә иде.* Г.Ибраһимов. *Җир йөзендә куерган артык фаҗигый хәлләр аның ачуын кайнатамы?* С.Поварисов

**ФАҖИР** *и. гар.* Азгын ир; бозык эшләр эшләүче; уйнашчы. --- *төшендә күрде: оҗмах түрендә утырыр. Сәваль итте: «Син бер дивана, фасикъ, фаҗир кеше идең, ничек бу дәрәҗәгә җиттең?» – диде.* К.Насыйри

**ФАҖИРӘ** *и. гар.* Фаҗир хатын-кыз. *Ул фаҗирә, шайтан ялчысы булып, тиз егетне табып китерде.* Г.Фәезханов

**ФАҖИРӘЛӘНДЕРҮ** *ф. иск.* Аздыру, бозу

**Фаҗирәләндереп бетерү** Тәмам азгынга чыгару, бозып бетерү

**Фаҗирәләндереп ташлау** *к.* **фаҗирәләндереп бетерү**. *---фаҗирәләндереп ташламакчы булдыңмы?* Г.Тукай

**ФАҖИРЛӘНҮ** *ф. иск.* Азу, бозылу

**Фаҗирләнеп бетү** Тәмам азгынга чыгу, бозык юлга басу

**ФА́ЗА** *и. гр.* 1) Табигать яки җәмгыять үсешендәге бер күренешнең яисә процессның аерым бер стадиясе, үсеш моменты. *Ватан сугышы тукталмады гына түгел, бәлки, дөрләп кабынып, яңа фазага керде.* Р.Әмирхан. *Йокының парадоксаль фазасы арыган минең тонусын торгыза, бинокуляр күрү сәләтен үстерә.* Могҗизалар энциклопедиясе

2) *биол.* Организмның индивидуаль үсешендәге махсус этап, бер чор. *Орлыкның балавызсыман өлгереш фазасы. Күбәләкнең курчак фазасы*

3) *астр.* Кояшның туры нурларыннан периодик кабатланып күренгән күк җисемнәре торышындагы аерым бер момент. *Бүгенге көндә астрономнар айның төрле фазаларын гаять төгәл рәвештә исәпләп чыгара ала, ләкин айның күренү вакытын билгеләүдә гомуми таралган, гомум кабул ителгән бер ысул-кагыйдә юк.* Мөселман календаре. *Яңа ай фазасы. Тулы ай фазасы*

4) *физ.* Тирбәлеш процессын вакытның һәр мизгелендә характерлый торган халәт, зурлык. *Алмаш ток фазасы*

5) Катлаулы физик, химик системаның бердәй үзлекләргә ия булган өлеше. *Сыек хәлдәге фаза. Газ хәлендәге фаза*

6) *геол.* Тау токымнарының теге яки бу характерын билгели торган иң кыска вакыт арасы

7) *эл.* Генератордагы уралманың аерым группасы һәм ток үткәрү өчен аңа тоташтырылган чыбык. *Менә шуларның берсе, трансформаторга якыны, өзелеп китеп, югары көчәнеш үткән фазага уралып тора. Бу инде, мөгаен, буран галәмәте... Кичә бигрәк тә нык котырынды бит.* Д.Бүләков

**ФА́ЗАЛЫ** *с.* Фазага мөнәсәбәтле. *Авылга бетоннан коелган электр баганалары утыртылды. Өч фазалы чыбыклар суздылар.* Т.Миңнуллин. *Фазалы тигезләнеш*

**ФАЗАН** *и. гр. зоол.* Кыргавылчалар семьялыгыннан атасы озын койрыклы, матур чуар йонлы булуы белән аерылып торган эре киек кош; кыргавыл. --- *эре бүрәнә стеналарда шамаилләр һәм ике фазан кошы чучелосы, ә түшәмдә – өстәл турысында – кырыклы лампа.* А.Расих. *Легендаларга караганда, заманында король Карл IV урманда фазан ата.* Кызыклы география

**ФАЗАНА́РИЙ** *и. рус* Урманда фазаннар үрчетә һәм асрый торган урын, фазаннар питомнигы

**ФАЗЕ́НДА** *и. порт.* 1) Бразилиядә зур терлекчелек яки җир эшкәртү хуҗалыгының утары

2) *сөйл. ирон.* Шәһәр читендәге йорт, дача. *– Менә шушы була инде безнең дача. – О-о! Фазенда шәп! Гүзәлия, мин сиңа өйләнәм. Баста! [Заһид:] – Юк, Роза апа кызын миңа бирә ул. Бакчада бит җир казырга кирәк, ә син ялкау.* Аманулла. *Фазендам бәләкәй генә инеш буенда.* К.Миңлебаев

**ФА́ЗЛӘН** *с. гар. иск.* Намуслы, өстен. *Ялангач калдыйсән, син һәр җәһәттән фазлән тәңредән.* Г.Тукай

**ФАЗО́МЕТР** *и. рус махс.* Алмаш ток чылбырындагы егәрлек коэффициентын яки ток һәм көчәнеш арасындагы фазалар аермасын үлчи торган прибор

**ФАЗЫЙЛӘ́Т** *и. гар.* 1) Яхшы сыйфатлылык, яхшы холыклылык. *Болар инде – бөтен фазыйләттән мәхрүм кешеләр.* М.Гафури

2) Өстенлек, артыклык. *Бу фазыйләтләрең һәр икесеннән дә бибәһрә улан.* Г.Тукай

3) Уңай як. *Әмма бераз салкынлылык булса, алар синдә булган фазыйләтне уйларга да куркалар.* Г.Тукай

**ФАЗЫ́ЙЛЬ** *с. гар. иск.* Укымышлы, акыллы, белемле; өстен. *Аларның берсе – шәһәребезнең шәһәр күрмеш мөлиясе бер галим вә фазыйль...* Дәрдемәнд. *Казанда бер фазыйль чыкты, алмас булып... Хәкаикъ диңгезендә гаувас булып.* М.Акмулла

**ФАЗЫЛ** *и. гар.* 1) Өстенлек, артыклык, камиллек. *И Ходаем, фазлың берлә көнне җылыт, үлгән дөнья яңа җаннар алсын имди.* Г.Тукай

2) Белемлелек. *Берәүгә фазыл бирсә Хак тәбарәк, кыйлыр һәр эшене аның мөбарәк.* Татар әдәбияты тарихы

3) Кешелеклелек, намуслылык. *Җаным ул, фазыл ит бәңа сән, улма җани җаныма.* Г.Тукай

**ФАИКЪ** *с. гар.* Башкалардан өстен, алда торучы. *Фикердә фаикъ, кавелдә садыйк.* Мәкаль

**ФАЙ** *и. фр. махс.* Аркылыга нечкә сырлары булган тыгыз ефәк тукыма

**ФАЙДА** *и. гар.* 1) Уңышлы, яхшы як, уңай нәтиҗә. *Кайгырудан файда юктыр.* Г.Тукай. *Ләкин моннан Җиһанша бабайга ни файда?* Ш.Камал

2) Рәт, мәгънә. *Баш күзеннән ни файда, күңел күзе күрмәсә.* Мәкаль. *Вакыт үтсә, үкенүдән һич файда юк.* М.Гафури

3) Яхшылык, игелек. *Җырлыймын, ләкин җырларымнан файда бармы халкыма?* Г.Тукай. *Кулымнан эш килсә, халыкка файдасы тия.* Г.Бәширов

4) Керем, табыш. *Һәр пар башына бер тәңкәдән никадәр файда алачакларын да исәпләп куйдылар.* Г.Тукай. *Бөтен чыгымнарыннан тыш сигез сум саф файда да калды.* Г.Ибраһимов

5) Ярдәм, уңай якка борып җибәрерлек тәэсир. *Яз җитәдер, файда юктыр, күпме гайрәтсә дә март.* Г.Тукай

6) Мәнфәгать, ихтыяҗ. *Мин шуны әйтергә телим: минем белүемчә, моңа кадәр берәүнең дә үз файдасы, үз зәвыгы өчен генә музыкант яисә артист булганы юк әле.* Г.Бәширов. *Гали мулла соңгы сүзләрен турыдан-туры үзенең шәхси файдасын күзәтеп сөйләде.* Ш.Камал

◊ **Файда бирмәү** Нәтиҗәсе булмау, көтелгән, өмет ителгән нәтиҗә килеп чыкмау. *Ул йортның табиблары барчасы дару итеп карадылар – файда бирмәде.* К.Насыйри. *Ләкин андый хәлләргә буш кул гына файда бирми.* Ш.Камал. **Файда китерү** Аерым мәнфәгатьләрне күздә тоту, кайгырту, яхшылык эшләү. *Ул, Бөек Октябрьдән соң, җаны-тәне белән бирелеп, революциягә бик зур файда китерәм, дип ышанып эшләүче советчыл, намуслы интеллигентларның берсе иде.* К.Тинчурин. *Фашистларны җаны-тәне белән сөйми, көне-төне Ватанына файда китерү турында уйлый.* Т.Әйди. **Файда көтү** Яхшылык өмет итү, ышану. *Чын дустан гына файда көтү мөмкин.* М.Гафури. **Файда тидерү** Яхшылык эшләү, яхшылык белән кайтару. **Файда тиерү** *к.* **файда тидерү**. *Бәлки мин шушы кадәр зәгыйфь вә көчсез бер мәхлук булсам да, бервакыт сезгә бер файда тиерермен.* Г.Тукай. **Файда тию** Яхшылык китерү, көтелгән уңай нәтиҗә булу. *Гакыл иясенә киңәш кыйлсаң, аның гакылы сиңа йогар вә аның гакылыннан сиңа файда тияр.* К.Насыйри. *Миңа үзенә дә файдам тия ич.* А.Әхмәт

**ФАЙДА́ ИТҮ** *ф.* 1) Ярдәм итү, булышлык күрсәтү, булышу. *Андый вакытларда мин иң кайгылы-хәсрәтле уйларны башыма китереп карыйм, --- ләкин берсе дә файда итә алмый, һаман көләсе килә.* М.Әмир. *Нинди могҗиза белән институтка эләккәндер, мөгаен, физикада һәм математикада осталыклары файда иткәндер!* Ф.Яхин

2) Яхшылык, игелек күрсәтү; уңай тәэсир итү. *Син миннән зарар күрдең, миңа файда итә торган белән торырсың.* Г.Исхакый. *Ике еллык авыл хәяты файда иткән, иман вә куәт арттырган.* Г.Ибраһимов

3) Керем алу, кулга табыш төшерү. *– Алма вә җимешләр алып базарга китереп сатсаңыз, шаять, күп файда итәрсез, – диде.* К.Насыйри

**ФАЙДАЛАНУ** *ф.* 1) Кирәкле ихтыяҗлардан, мәнфәгатьләрдән чыгып куллану. *Алпавыттан тартып алынган атларны, авыл хуҗалыгы машиналарын чиратлашып файдаланалар.* Г.Ибраһимов. *--- фрау аңа [Ишкәйгә] өйалдындагы радиоалгычны да файдаланырга рөхсәт итте.* Т.Әйди

2) Чарага, әмәлгә әйләндерү. *--- яңа элементлардан файдаландылар һәм татар музыкасыннан шактый алга киттеләр.* М.Җәлил. *Тормыш-көнкүреш образларыннан оста файдалана.* Г.Нигъмәти

3) Хакимлектән, хокукларыннан, эш урыныннан файда алу, аларны үз мәнфәгатьләрендә куллану. *Ләкин мәкалә авторы, моның белән генә чикләнмичә, Беляевны үз мәнфәгате өчен, урыныннан файдаланып, «аеруча зур күләмдә дәүләт малын үзләштергән» (ә турысын гына әйткәндә, урлаган) җинаятьче итеп күрсәтә.* Ә.Еники. *Усал телләргә ышансаң, алар Хәлил хакында мондый гайбәтне яратып тараттылар. Янәсе, милициядә эшләвеннән файдаланып, ул бер кыз үстереп ятучы укытучы ханымны юлдан яздырган.* Т.Галиуллин

4) Мөмкинлекләрне куллану, мөмкин булганнан файда алу. *Бик күптән Гәүһәргә күз атып йөргән Йосыфҗан менә шул моменттан файдалана белде.* Г.Ибраһимов. *Уҗым культуралары җирдәге дымны 1,5–2 тапкыр күбрәк файдалана алалар.* Чәчү әйләнешләре – игенчелекнең нигезе

5) Ия булу, хуҗа булу. *Ләбәҗдәге уку йорты безнең авылдагы төсле мәктәп түгел, мәдрәсә дип атала, аның җитәкчесе дә мулла яисә хәлфә түгел, ә дәмулла һәм бохара хәзрәт дигән титуллар белән файдалана иде.* Ш.Камал. *Октябрь революциясенә кадәр музыка татар культурасы үсешендә киң хокук белән файдалана алмады.* М.Җәлил

6) Үзе өчен эшләтү, башкалар мәнфәгатенә эшләргә мәҗбүр итү. *Сиздермичә шулай, үз эшенә файдалана фашист аларны.* Ә.Исхак. *Аксөякләр тоткын коллар хезмәтеннән файдаланалар.* Урта гасырлар тарихы

**Файдалана башлау** Файдаланырга керешү. *Эш коралларыннан файдалана башлау кешегә генә хас эшчәнлек – товар җитештерүне барлыкка китерә ---.* А.Низамов

**Файдалана төшү** Тагын да бераз файдалану, күбрәк, артыграк, төгәлрәк файда күрү. *Ул, бу хәлдән тиешенчә файдалана төшәргә карар биреп, бөтен ораторлык куәтен җибәреп сөйли башлады.* Ш.Усманов

**Файдаланып бетерү** Тулысынча, беткәнче файдалану; бар булган чаралардан ахырга кадәр файдалану. *Көн кичкә авышкач, монтажчы егетләр ашыга төштеләр, килгән измәне файдаланып бетерергә кирәк иде.* Н.Хәсәнов

**Файдаланып бетү** Барысыннан да тулысынча файдалану. *--- диалогларда нык сизелгән чагылыш теориясеннән файдаланып бетми.* Х.Сарьян

**Файдаланып йөрү** Һәрвакыт, даими рәвештә файдалану

**Файдаланып калу** Булган мөмкинлекләрдән вакытында файдалану, файдаланырга өлгерү. *Халык, көннең аязлыгыннан файдаланып калырга дип, кырга ашыкты.* А.Шамов. *Һәркем яз бәйрәменнән күбрәк файдаланып калырга, аның иркен һавасын күкрәгенә күбрәк тутырып калырга ашыга.* Ә.Фәйзи

**Файдаланып карау** Тикшерү, сынау максаты белән файдалану. *Син менә бер генә мәртәбә үз көчеңнән файдаланып кара әле. Тылсымлы яулык белән кем дә булдыра аны.* Ә.Хәсәнов

**Файдаланып килү** Һәрвакыт, даими рәвештә, электән үк файдалану. *Буржуазия, хосусый милек «изгелеген» халык миенә сеңдерү өчен, бөтен юллардан да файдаланып килде.* М.Җәлил. *Татар халкының төрки телле бабалары --- хайван исемнәренә нигезләнгән уникееллык календарьдан файдаланып килгәннәр.* С.Шәрипова

**Файдаланып ташлау** Азга гына, кыска вакытка гына файдалану. *Атом уты көйрәгән корылмалардан ерак та түгел бер якта бер-ике мәртәбә файдаланып ташланган автомашиналар, тракторлар һәм башка «төр техника зираты» санап бетергесез күп.* Ә.Салах

**Файдаланып тору** Даими рәвештә, еш кына, әледән-әле файдалану; вакытлыча файдалану. *Чөнки ул дин һәм бөтен агу-томаннарны шулай ук хезмәт халкына каршы, аларны изү өчен файдаланып тора.* М.Җәлил. *Юрий Петрович! Кырык икенче реверска бер створка җитми. Әллә экспортка дигәнне файдаланып торыйкмы?* Н.Хәсәнов

**ФАЙДАЛАНУЧЫ** *и.* Нәрсәдән дә булса файда алучы, кулланучы. *Сәнгать әсәрләренең социаль табигатен аңлата торган «заказчы һәм башкаручы», «иҗат итүче» һәм «файдаланучы» кебек проблемаларга да ул бары тик узып барышлый, өстән-өстән генә кагылгалый.* М.Госманов. *Татарстан Министрлар Кабинеты чыгарган 346 нчы карар нигезендә андый ташламалардан файдаланучылар шактый.* Сөембикә

**ФАЙДАЛАНЫРЛЫК** *с.* Файдаланырдай, файдаланырга мөмкин булган. *Дошман файдаланырлык бер әйбер дә калдырмыйча чыгабыз.* Ш.Усманов

**ФАЙДАЛЫ** *с.* **1.** 1) Файда китерә торган, файдасы тиярлек. *Киләчәк көндә хөрмәтле вә файдалы кешеләр булуыгызны ата вә анагыз һәрвакыт өмет итеп торалар вә Аллаһы Тәгалә хәзрәтеннән сорыйлар.* Р.Фәхреддинов. *Әйе, сез зур кешеләр булдыгыз, илгә, дәүләткә кирәкле, файдалы кешеләр булдыгыз, хәзер шуның әҗерен күрәсез, рәхәтен чигәсез!* Ә.Еники

2) Дәвага яраклы, шифалы. *Тәмле дә, күңелле дә булу өстенә файдалы да дип беләм мин сагызны. Тешләрне, яңак мускулларын ныгыта.* Р.Фәттахова. *Терелү-яшәү өчен, җәнлекләр дә нәкъ менә кирәкле, файдалы үләнне барып таба...* Ш.Галиев

3) Табышлы, төшемле. *Файдалы сәүдәләр, һөнәрләр тирәсендә яһүд тә немец кына.* Ф.Әмирхан. *Мондый шартларда эшмәкәрләргә кыйммәтрәк әйберләр белән сату итү файдалырак, чөнки табыш күбрәк.* Ф.Зариф

4) Әһәмиятле, тормыш өчен кирәкле булган, мөһим. *Әнисе аңа бик файдалы киңәшләр, хәйләле юллар өйрәткән дә икенче көнне тагын да ауга киткән.* А.Алиш. *--- бу хезмәтебез кирәкле, файдалы кулланма була алса, без үз максатыбызга ирештек дип санар идек.* И.Низамов

5) Аерым мәнфәгатьләрне яклаган, төрле максатларга яраклаштырылган. *Үз тәкъдимнәребез белән барабызмы, чакырып алалармы, судка барабызмы – һәркайда үзебезгә файдалы мәсьәләләрне куярга тырышабыз.* Р.Вәлиев. *Бу эштә тарихка үзе өчен файдалы ялган сәхифәләр өстәү һәвәслеге белән Иван Грозный аеруча танылa.* Р.Вәли

6) Халык хуҗалыгы өчен кирәкле, әһәмиятле, кыйммәтле. *Әфганстанда күптөрле файдалы казылмалар: нефть һәм күмер, тимер рудасы, алтын һәм көмеш, төрле металл рудалары, кыйммәтле ташлар бар.* Чит илләрнең экономик географиясе. *Геологоразведчиклар илебезнең төрле почмакларында, моңа кадәр кеше аягы басмаган сукмаклар буйлап, файдалы казылмалар эзлиләр.* Казан утлары

**2.** *рәв. мәгъ.* Уңайга, җайга китереп. *Син бер дә уңайсызланма, Әнвәр, мәгариф органнарында эшләү үзең өчен дә файдалы булыр.* Ш.Камал. *Үзе файдалы тапканча тота ала иде.* Г.Әпсәләмов

**ФАЙДАЛЫК** *и. ялг. к.* **файдалылык**. *Менә бит ул күмәк хуҗалыкның файдалыгы кайда, иккүзем!* Һ.Такташ

**ФАЙДАЛЫЛЫК** *и.* Файдалы булу. *Вәхшиләрнең башына бергәләшмәкнең файдалылыгы фикере урнашкач, аларның һичберсе бергәләшмәктән аерылмаска вәгъдәләр куештылар.* Г.Тукай

**ФАЙДАСЫЗ** *с.* **1.** 1) Файдасы булмаган, файда итми торган. *Файдасыз низаг вә җәнҗалны бетермәк булдылар.* М.Гафури. *Син яшәмә җирдә файдасыз бер түмгәк булып тигез урында.* М.Җәлил

2) Табыш китерми торган, төшемсез. *Хәйләсезгә дөнья файдасыз.* Әйтем. *Төзелеш әйберләренә, ягулыкка, утка бәяләр арту нәтиҗәсендә, урындык ясап сату файдасыз, зарарлы, чыгымлы була башлады.* Т.Галиуллин

3) Нәтиҗәсез, өметсез, кирәксез. *Колхоз җитәкчеләре һәм бригадирлар аларны эшкә тартып булмый торган көчсез, файдасыз артык тамаклар дип кенә карыйлар.* М.Җәлил

**2.** *рәв. мәгъ.* Бушка, тиккә. *Ләкин хәзер артык сүз көрәштерүне файдасыз тапты.* Ш.Камал

**ФАЙДАСЫЗЛЫК** *и.* Файдасыз булу. *Карт улының табигатен яхшы белә иде, сүз көрәштерүнең файдасызлыгын аңлады.* Г.Ибраһимов. *Озак сөйләшеп торуның файдасызлыгын төшенеп алган лейтенант янындагы солдатка эндәште.* Г.Минский

**ФАЙДАСЫНА** *бәйл.* Өчен. *Син аны якламасаң, Һидият тә аның файдасына кул күтәрми иде.* Ш.Камал. *Ялгышмасам, ул кичә мәдрәсә ташлап чыккан шәкертләр файдасына ясалды.* А.Расих

**ФАЙЛ** *и. ингл. информ.* Компьютер хәтерендә саклана торган мәгълүматның бер исем астындагы җыелмасы. *Кирәкле файлны эзләп табып ачасың да мәгълүматны аласың.* Ф.Яруллин. *Файлны саклау*

**ФА́КЕЛ** *и. гр.* 1) Таяк очындагы чүбеккә яна торган катнашма сеңдереп, шуңа ут элдереп файдаланыла торган яктырту җайланмасы. *Теләк булса, порох базына янган факел тотып төшәсең.* Ф.Кәрим. *Төн икән, караңгы, Насыйбулла әфәнде безнең янда --- факел тотып тора.* А.Расих

2) Нефтькә ияреп чыккан табигый газ агымына ут элдерүдән күтәрелгән

ялкын. *Ул якта күк төнлә дә кызгылт, газ факелларының шәүләсе төшә.* С.Сөләйманова. *Кая карама, анда буровой вышкалары утыра, факеллар яна.* Х.Камалов

◊ **Факел булу** Әйдәп бару, маяк булу. *Факел булып ян ил өчен, бөек илнең бөек кешесе.* Ә.Ерикәй

**ФА́КЕЛЧЫ** *и.* 1) Факел йөртүче

2) Ут төртүче, яндыручы. *Ә мондый ерткычлыкларны эшләү өчен, үзенең башкисәрләреннән [немецлар] заслоннар, факелчылар калдыра.* Ә.Айдар

**ФАКС** *и. лат.* 1) Электрон почта ярдәмендә текст, схема, сызым, фотографияләр җибәрә торган элемтә системасы. *Конференциягә килүчеләр хезмәт күрсәтүне тулысынча компьютерлаштырып алып бару тәртипләрен интернет, ксерокс, факс, электрон почта, видеотелефон эшчәнлекләре белән тәфсилләп карадылар.* Т.Нәҗмиев. *Факс аша Удмуртия хәрби комиссарына килгән хатның күчермәсен батырның туганнарына җиткерәләр.* Мәдәни җомга

2) Шундый элемтә системасы буенча алынган материал, мәгълүмат. *Факс кабул итү*

3) Шул элемтә аппараты. --- *[авыл] өйләрендә, космик корабтагы кебек, бөтен электрон җиһазлар шыплап тулган: монда интернет та эшләп тора, сканерлар, факслар, видеокамералар, лазерлы принтерлар – барысы да авылга хезмәт итә.* Ф.Бәйрәмова. *Соңгы модельдәге факс. Офиска факс урнаштыру*

4) Шундый элемтә өчен урнаштырылган аппарат номеры. *Оешманың телефонын һәм факсын язып бирү*

**ФАКСИ́МИЛЕ** *и. лат.* **1.** Имзаның, язу рәвешенең, документның, кульязманың, картинаның төгәл күчермәсе. *Галимнәр «Нәһҗел-фәрадис»нең Мисыр аша Истанбулга эләккән бу кульязмасын да Идел буендагы Сарай шәһәреннән чыккан дип исәплиләр, төрек галиме Я.Экман аның факсимилесын бастырып чыгара.* Татар әдәбияты тарихы. *Борынгы кульязмаларның факсимилеларын булдыру*

**2.** *с. мәгъ.* Төгәл кабатланган. *Факсимиле басма*

**3.** *рәв. мәгъ.* Үзгәртмичә, төгәл кабатлап. *Авторның кульязмаларын факсимиле нәшер итү*

**ФАКС-МОДЕ́М** *и. лат. информ.* Факслар кабул итә һәм җибәрә торган модем

**ФАКС-МОДЕМЛЫ** *с.* Факс-модемы булган

**ФАКТ** *и. лат.* **1.** 1) Булган хәл, вакыйга, хакыйкый чынбарлык. *Безнең зур өметләребез, матур хыялларыбыз тормыш фактына әйләнде, дигәндә генә, бөтенесе шулай киредән сүтелерме икәнни?* Г.Ибраһимов. *Чемпионда районыбызның алдынгы колхозын җитәкләүче Мостафа Фәләхов үзе дип, бу фактка аерым игътибар юнәлттеләр.* Р.Мөхәммәдиев

2) Мисал, аерым очрак. *Әмма көтмәгәндә шундый факт килеп чыккач, кызыксынып куясың.* М.Җәлил

3) Бәхәссез нигез, дәлил. *Бу факт опера театрының художество җитәкчелегенә яхшы ук талантлы көчләр тартылуын күрсәтә иде.* М.Җәлил

**2.** *хәб. функ. сөйл.* Бәхәссез дөреслек, чынбарлык. *Ә инде биргән эшне алырга теләмисең, – анысы факт.* Р.Ишморат

**3. фактта** *рәв. мәгъ.* Чынлыкта, чынында. *Фактта ул производство новаторы булудан туктады.* Б.Камалов. *Исемлек фактта төзелмәгән*

**ФА́КТИК** *с.* 1) Фактта булган, чын, хакыйкый дәлилләргә таянган. *Тарихи тикшеренүләрендә автор татар, рус, гарәп, фарсы һәм төрек телләрендә язылган беренче кульязма тарихи чыганаклардан җыелган фактик материалларга таянып гамәл кыла.* М.Госманов. *«Төгәл саннарын, даталарын да әйтим әле», – дип уйлады Таһир һәм иң элек фактик материаллардан башлады.* Г.Ахунов

2) Чын, чынбарлыктагы, факттагы. *Гәрчә рәсмән гәзитнең мөхәррире һәм нашире башта М.Путиляков, аннары Ф.Туктарый һәм С.Рәмиев исәпләнсәләр дә, «Таң йолдызы»ның фактик җитәкчесе, аңа рух биреп торучы кеше Г.Исхакый була.* Р.Әмирхан

**ФАКТОГРА́ФИК** *с.* Фактографиягә нигезләнгән, фактларны анализ ясамый гына теркәгән. *Иске дәвер мәдәниятебез һәм әдәбиятыбыз тарихын өйрәнгәндә, без «Асар» материалларыннан башка фактографик төгәл һәм фәнни эзлекле рәвештә гамәл итә алмаячакбыз.* М.Госманов. *Чынлыкта гамәлдәге белем – фәнни эшчәнлекнең шушы вакытка бердәм нәтиҗәсе, фактографик тасвирламасы файдаланыла.* Фәнни Татарстан

**ФАКТОГРА́ФИЯ** *и. лат.-гр.* Фактларны анализламыйча гына тасвирлау; фактларны теркәү, аларны санап китү. *Дөрес, бу бүлекләрдә, алдагыларында да сизелеп киткәндәй, фактография алыми үзен ныграк күрсәтә.* М.Госманов

**ФАКТОЛО́ГИЯ** *и. лат.-гр.* Фактик материалларны санап, шулар нигезендә бирелгән аңлатма, фактларны тасвирлап бирү, документальлек

**ФА́КТОР** *и. лат.* Берәр процессны, вакыйганы тудыра торган шарт, сәбәп, этәргеч көч. *Электрон хисаплау машинасы, теге яки бу тискәре фактор булган тәкъдирдә, күлнең үзен ничек тотасын шактый төгәл исәпләргә мөмкинлек бирәчәк.* Р.Мостафин. *Әмма исереклек җинаятьне арттыручы фактор гына бит.* Х.Вәлиәхмәтов

**ФАКТО́РИНГ** *и. ингл.* Сәүдә-комиссия эшчәнлегендә арадашчылык хезмәте. *«Татфондбанк» һәм «Интехбанк» клиенты булган эшмәкәрләргә ярдәм итү өчен, факторинг хезмәте булдырылды.* Шәһри Казан

**ФАКТО́РИЯ** *и. ингл.* 1) Колония яки бәйле илләрдә һәм өлкәләрдә чит илләрнең сәүдә конторасы һәм сәүдәгәрләр бистәсе. *Сәүдә флоты да үсә, илдән ерак булган чит җирләрдә хәрби ныгытмалар, сәүдә факторияләре барлыкка килә.* Казан утлары

2) Гомуми торак массивлардан еракта урнашкан промысел тармакларындагы социаль-тәэминат пункты. *Авырсак, фельдшер килеп карый, фактория безгә бөтен кирәк-яракны биреп тора.* Казан утлары

**ФА́КТОРЛЫК** *и.* Сәүдә-комиссия өлкәсендә арадашчылык

**ФАКТУ́РА** *и. лат. махс.* 1) Сәнгать әсәрләрендә художество техникасы үзенчәлеге. *Рәсемнәрне ул --- һәркайсын җентекләп карый, кайда фактура ачылмаган, кайда шәүлә-күләгә дөрес салынмаган – ике-өч сүз белән генә аңлата.* Казан утлары

2) Агач, мәрмәр, тукыма һ.б.ш. материалларның эшкәртелү үзенчәлеге яки өслекләренең төзелеше. *Бөтенләй башкача фактурадагы инструмент ясарга кирәк булып чыкты.* Казан утлары

3) Җибәрелгән товарның исемлеген, хакын, микъдарын күрсәткән документ, счёт. *Аеруча май, чәй-шикәрне бик аз җибәргәннәр, Тутаев, түземен югалтып, базадагы «бюрократларны» сүгеп тә карады, әмма, аңа карап, фактурадагы килограммнар артмады.* И.Салахов

4) Йөз, килеш-килбәт, фигура кебек тышкы үзенчәлекләр; типаж. *Тышкы*

*фактурасы белән Назлыбикәдән ким түгел.* Ю.Әминов

**ФАКУЛЬТАТИВ** *с. фр.* **1.** 1) Катгый таләп ителмәгән, икенчел. *Факультатив билге. Факультатив җәя*

2) Аерым фәннәр буенча белемне тирәнәйтү максаты белән оештырылган, өстәмә белем алу мөмкинлеге булган. *Иптәш кызым белән факультатив занятиеләрдән химияне сайладык.* А.Гыйләҗев. *Факультатив дәресләр*

**2.** *и. мәгъ.* Өстәмә дәрес. *Математикадан факультатив*

**ФАКУЛЬТЕТ** *и. нем.* Югары уку йортларында фәннең аерым тармаклары буенча тупланган бүлек. *Хәзер транспорт инженерлары институтының кичке факультетында укый, шул ук вакытта автомобиль заводы төзелешендә эшли.* А.Шамов. *Ул укыган гуманитар факультетта фәлсәфә, социология, психология фәнен тирәнтен өйрәнәләр.* З.Хөснияр

**ФАКЫР** *и. гар. сөйл.* Мескен, бичара, бахыр. *Эшлидер, тик эшли эшче мескен, факыр.* Г.Тукай. *Коточкыч көчле бүрем шүрләгән икән, факыр.* Х.Туфан

**ФАЛ** I *и. голл. махс.* 1) Корабльләрдә җилкәннәрне, сигнал флагларын күтәрү өчен хезмәт итә торган бау

2) Үзеннән-үзе ачылу өчен, парашют боҗрасыннан самолёт кабинасына тоташтырылган бау

**ФАЛ** II *и. гар.* 1) Күрәзә, юрау. *Фал нәрсә икәне һәркемгә мәгълүмдер.* Г.Тукай. *Кешеләр, бөтен өметләре сүнгәндә дә, фал, юрау, төш кебек сихер хасиятләренә ябышып, чарасызлыктан котылып калырга теләделәр.* Г.Гыйльманов

2) Яхшыга яки начарга юралган нәрсә, берәр нәрсәнең билгесе, галәмәте. *Эш мондый юнәлеш алса, хәерле фал түгел бу.* А.Расих. *Әйбәт фалмы, түгелме – район үзәгенә йөрүче пазикка әллә нәрсә булды.* З.Фәтхетдинов

◊ **Фал ачу** Фал китабының теләсә кайсы битен ачып, андагы текстка бәйләп, киләчәкне юрау яки үткәнне әйтү. *Язып алган догаларны вә яхуд ачтыгыз сез фал.* Г.Тукай. *Фал ачканда, гомерләр китабыннан укыдым шундый җөмлә бер бабыннан.* Ә.Исхак. **Фал карау** *к.* **фал ачу**. **Фал китабы** Фал ачып күрәзәлек итү өчен махсус билгеләнгән китап; фалнамә. *Фал китапларын, гадәттә, кумәк уеннар вакытында ачканнар.* Г.Гыйльманов. *Моңа кадәр күрәзәче, имтомчыларга бер тамчы да ышанмаган, уйдырма дип кенә караган ана баласы хакына ул хатынга фал китабын укытып карарга уйлады.* Безнең гәҗит

**ФАЛА́НГА** I *и. гр.* 1) Берничә шеренгадан торган авыр коралллы җәяүле гаскәрнең тыгыз, сугышчан строе. *Борынгы Рим фалангасы*

2) Утопик социализм тарафдары Ш.Фурье тәгълиматында 1600–1800 кешедән торган община, коммуна

3) Тигез итеп тезелгән саф

**ФАЛА́НГА** II *и. гр. анат.* Бармак сөяге. *Атсыз бармакның бер фалангасын сындыру*

**ФАЛА́НГА** III *и. гр. зоол.* Бөе, агулы үрмәкүчсыман бөҗәк. *Әнисе шунда ук урыныннан торып читкә тайпылды: – Фаланга дисеңме, улым, нәрсә соң ул? – Ул тешләсә, әнкәй, түзә алмаслык авыртуга дучар буласың, хәтта үлүең дә мөмкин.* Казан утлары

**ФАЛА́НГАЧЫ** *и.* 1) Фаланга сугышчысы

2) Фаланга (коммуна) әгъзасы

**ФАЛЕРИСТ** *и. рус* Фалеристика белән шөгыльләнүче кеше

**ФАЛЕРИ́СТИКА** *и. лат.* Орден-медальләр, аеру билгеләре, значок һәм жетоннар җыю һәм өйрәнү шөгыле. *Значоклар җыю белән мавыгу нәкъ менә фалеристика дип атала да.* Авыл офыклары

**ФАЛИҖ** *и. гар.* < *гр. иск.* **1.** Паралич. *Докторлар, йөрәгән фалиҗ суккан, диделәр.* Г.Ибраһимов

**2.** *с. мәгъ.* Паралич суккан, параличланган. *Теге фалиҗ хатын янындагы хатынга ишарә кыла.* Г.Исхакый

**ФАЛЛАНУ** *ф.* Киләчәкне юрау, күрәзәлек итү. *Тукта, үзем белән вә хәзерге заманыбыз азмы-күпме шөһрәт тапкан кешеләр тугрысында шушы словарьны ачып фалланыйм әле.* Г.Тукай

**ФА́ЛЛОС** *и. гр.* Кайбер халыкларда табигый башлангыч мәгънәсендәге табыну объекты буларак ирләрнең җенес әгъзасы яки аның сыны, сурәте. --- *заманында ирләр җенес әгъзасының кот, бәрәкәт, үрчем, уңдырышлылык фетишы итеп каралуы, ягъни фаллос культы булганлыгы да мәгълүм.* М.Бакиров. *Таш фаллос*

**ФАЛЛЫ** *с.* Фал буларак кулланырлык. *Мин бу сүзләрне --- яман фаллы вә мәшъум исемнәр тагылганына эчем пошканнан яздым.* Г.Тукай

**ФАЛНАМӘ** *и. гар.-фар.* Фал ачу китабы. *Фалнамә ачып, гаиптән хәбәр белеп була торган булса, большевиклар ачар иде ул фалнамәне.* Р.Ишморат. *Календарь фалнамәсе бабаларыбызның күчмә тормыш вакытындагы тәҗрибәләре нигезендә төзелгән.* С.Шәрипова

**ФАЛЧЫ** *и.* Юраучы, күрәзәче, фал ачучы. *Бөтенләй аптырап беткәч, чакырды хан багучыны, мөнәҗҗим, фалчыны һәм дә хәким исмен тагучыны.* Г.Тукай. *Тирә-әтрафтагы мәшһүр фалчыларны чакыртып, угрыларны фаш итүләрен сорасам да, алар миңа ярдәм итә алмадылар.* Ә.Еники

**ФАЛЬСИФИКАТ** *и. лат.* 1) Тиешле составка нигезләнмәгән, алдап ясалган продукт, ялган товар. *Тагын бер проблема: пальма мае кушылган фальсификат ясаучыларның күпчелеге Татарстанда түгел, ә Мәскәү, Түбән Новгород, Калининград һәм Самара өлкәсендә.* Акчарлак

2) Чынбарлык белән бутап, бозып күрсәтелгән уйдырма

**ФАЛЬСИФИКА́ТОР** *и. лат.* Чынбарлыкны, дөреслекне бозып күрсәтүче. *Тарихи чынбарлык фальсификаторлары СССРда милләтчелекнең яңаруы турында сафсата сату белән генә чикләнмиләр, алар безнең илдәге күпсанлы милләтләрнең үзара туганнарча дус яшәвен дә, бер-берсенә карусыз ярдәмләшүен дә инкяр итәргә тырышалар.* Казан утлары

**ФАЛЬСИФИКА́ТОРЛЫК** *и.* Фальсификатор эшчәнлеге. *Фальсификаторлык белән шөгыльләнү*

**ФАЛЬСИФИКА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Ялган, чынбарлыктагыча булмаган, бозып күрсәтелгән эш-хәл, уйдырма. *Чөнки элекке большевистик субъектив рухтагы тарихи китапларда аның эшчәнлеге, иҗаты хакында хөкем сөргән тупас фальсификациядән арыныр өчен, моңар хәтле басылып чыккан ике-өч мәкалә генә җитми.* М.Госманов. --- *фәндә фальсификация юлына басканнар.* Ә.Кәримуллин

2) Ялган документлар белән эш итү; сәнгатьтә төп нөсхә урынына аның күчермәсен тәкъдим итү белән бәйле эшчәнлек. *Сатуга куелган Рубенс картиналары яхшы эшләнгән фальсификация булып чыкты*

3) Баю максаты белән, сату-алу әйберләренең (бигрәк тә азык-төлекнең) составындагы табигый ингредиентларны арзанлырак, сыйфатсызрак ише белән алмаштыру

**ФАЛЬСИФИКА́ЦИЯЛӘҮ** I *ф.* 1) Чынбарлыкны бозып, үзгәртеп күрсәтү

2) Нәрсәнең дә булса тышкы күренешен саклаган хәлдә, сыйфатын, составын начар якка үзгәртү. *Кофены фальсификацияләү. Эчемлекләрне фальсификацияләү*

**ФАЛЬСИФИКА́ЦИЯЛӘҮ** II *и. к.* **фальсификация**. *Күп кенә Көнчыгыш халыкларына тагылган бу кушамат байтак кына төрки халыкларның, бигрәк тә хәзерге татарларның тарихын, килеп чыгышын фальсификацияләүгә юл ача, хаталарга китерә.* Ә.Кәримуллин. *Тарихны һәм тарихи чыганакларны фальсификацияләүнең күп гасырлык тарихы бар.* Мирас

**ФАЛЬСТАРТ** *и. ингл.* 1) *спорт* Вакытыннан алдарак алынган старт

2) *күч.* Ни булса да эшләү өчен ясалган уңышсыз омтылыш

**ФАЛЬЦ** *и. нем. махс.* 1) Ике калайны тоташтырган бөгелеш, җөй

2) Ырмау, уем, паз

3) Басма кәгазь табагының бөкләнү урыны

**ФАЛЬЦЕТ** *и. ит.* 1) *муз.* Ирләрнең үтә югары регистрда җырлау ысулы. *Аның тавышы көчсез, ул, күбесенчә, фальцет белән җырлый иде ---.* Р.Батулла

2) Ирләрдә хатын-кыз тавышына охшаган нечкә тавыш. *Гаҗәеп кыяфәткә – оратор позасына басып, карлыккан, өзелә торган фальцет белән дөрес, хак сүзләр сөйли.* И.Илялова

**ФА́ЛЬЦЛАУ** *ф.* 1) Фальц ясау, бөгү. *Түбә калаен фальцлау. Табаклы кәгазьдән китап битләрен фальцлау*

2) Ырмау алу (бүрәнәдә, тактада, борыста һ.б.)

**ФАЛЬШЬ** *и. лат.* **1.** 1) *муз.* Ялгыш башкарылган нота, тонны дөрес алмау. *Берәр җырда фальшь сизүгә тузынып чыгып китә торган Илһам Шакиров ахырга кадәр түзеп утыра алыр идемени юкса?* Ватаным Татарстан

2) Хата, ялгышлык. *Бу гыйльми форумда 20 дән артык тарих, филология фәннәре докторлары, академиклар да катнашты, шуларның ник берсе бу фальшьны кире каксын... аларның барысы өчен дә татар теле монгол теле булып санала икән.* Ә.Кәримуллин. *--- бу образ, аңга, күңелгә тәэсир итүдән элегрәк, борынга бәрә башлады. Кыскасы, ул шаблонланган әдәби фальшь булып яңгырый.* Р.Харис

3) Алдау, ялган, ясалмалык. *Егетнең тавышындамы, сүз чыгышындамы, елмаюындамы – нәрсәсендәдер бер ясалмалык, бер фальшь чыкты.* Г.Ибраһимов. *Ул [Хәсән Туфан] тудырган шигырьләрдә риялылык, фальшь табу мөмкин түгел.* Ф.Галимуллин

**2.** *с. мәгъ.* Ялгыш, ялган, хата. *Соңгый, ягъни ясалма, фальшь акча кебек ялган шигырь бу.* М.Әмир

**ФАМИ́ЛИЯ** *и. лат.* 1) Борынгы Римда гаиләнең хокукый-хуҗалык бердәмлеге (фамилиягә, гаилә әгъзаларыннан тыш, коллар һәм клиентлар да кергән)

2) Тулы исемдә кешенең үз исеме һәм отчествосыннан соң килә торган, ата-баба исеменнән яки кушаматыннан төзелгән нәсел атамасы. *Кыска, ачык язылган фамилия белән түгел, номер белән кырык кул куелган.* Г.Ибраһимов. *Тукаев дигән фамилияне шәкертләрдән берәү дә белмәде.* Ә.Фәйзи

3) *иск.* Гаилә. *Нинди граф, нинди князь әллә нинди приказчикларга үзенең фамилия сәгатен биргәнен күргәнең бар?* Г.Исхакый

**ФАМИ́ЛИЯДӘШ** *и.* Кардәшлектә булмаган, әмма бер үк фамилия йөрткән кешеләрнең һәрберсе. *Юк ла, нинди актёр булыйм мин, фамилиядәш, адаш ул миңа. Мин – башка, ул очарга яратылган, без – шуышып йөрергә.* Р.Камалетдинова

**ФАМИЛЬЯР** *с. фр.* Артык иркен, тартынусыз, тәкәллефсез. *Тәзкирә апа, карталар аралаштыра-аралаштыра, фамильяр тон белән: – Әйдә, Сөләйман, – диде.* К.Тинчурин. *Җәмилә Закировна, шәкертләре белән фамильяр мөнәсәбәтләргә керергә бик үк яратмаса да, Дәүләтшинның теләгән хупланы – Ләйлә белән үзе үк таныштырды.* М.Маликова

**ФАН** *и. гр.* *Пан* сүзеннән фонетик үзгәреп ясалган сүз: әллә кем, үзенә күрә генә түгел адәм. *Кунак-төшеменең бер дә иге-чиге булмады, өч көн буенча хан да фан килделәр.* М.Мәһдиев

**ФАНАР** *и. сөйл. к.* **фонарь**

◊ **Фанар кабызу** Эз калдырырлык итеп сугу, сугып кызарту, кан савып, күгәргән урын барлыкка китерү. *Юк ла, оятыннан кызармаган ул, хатын-кызга бәйләнгән өчен яңагына фанар кабызганнар, шуңа кызарган.* М.Парсин. **Фанар утырту** *к.* **фанар кабызу**

**ФАНАТ** *и. рус* **1.** Берәр төрле агым, артист, музыкаль группа, спорт командасының казанышларын табыну объектына әйләндерүче зат. *Берәздан «Кадриль» белән «Валет» шактый зур төркем булып җыелырга өлгергән фанатлар тирәсендә иде.* М.Хәсәнов. *Нәрсә чәйнәп яши – Меңләп мисез фанат – җанатар?!* Р.Рахмани

**2.** *с. мәгъ. к.* **фанатик** II. *Рөстәм Кәлимуллин – үзе дә фанат җитәкче, бөтен җаны-тәне белән булсынга йөрүче шәхес.* Т.Нәҗмиев

**ФАНАТИЗМ** *и. лат.* Нинди дә булса идеяләргә, карашларга чиктән тыш бирелгәнлек. *Моның сәбәбе наданлык вә фанатизмдыр.* Ш.Мөхәммәдев

**ФАНА́ТИК** I *и. лат.* 1) Үз карашларына, диненә артык инанган, башкалардан да шуны ук таләп итә, янәшәсендә аның белән бер фикердә булмаганнар белән тыныч яши алмый торган кеше. *Габдулла аңа бер сүз дә төшендерә алмады, фанатик кызганнан-кыза барды.* Ә.Фәйзи. *Ул инде яңадан тәрбияләнә алмаган һәм деспотка, диндар фанатикка һәм, җае чыкканда сылтау табып, эштән баш тартучы бер ялкауга әверелгән.* Кызыклы психология

2) Үз хезмәтенә, идеяләренә, карашларына чын күңелдән бирелгән зат. *Галим – әнә аталы-уллы Арбузовлар, Камайлар. Үз эшләренең фанатиклары.* М.Мәһдиев. *Алай да сез бик үҗәт кеше, фанатик.* Г.Ахунов

**ФАНА́ТИК** II *с.* 1) Үз карашларына, диненә артык инанган, башкалардан да шуны ук таләп итә, аның белән бер фикердә булмаганнарга түзми торган. *Аны [Баязитны] Каргалының биш йөз шәкертле, кара, надан, фанатик мәдрәсәсенә салалар.* Г.Ибраһимов. *Фанатик Казан татарларының тискәрелеген җиңеп ачылган Русско-татарская школада авторитетлы татар укымышлыларыннан беренче булып эшләүче кем иде? – Мәрҗани.* М.Госманов

2) Үз идеяләренә, хезмәтенә үтә бирелгән. *Шуңа күрә минем тормышта фанатик врач булуым сезгә гаҗәп тоелырга тиеш.* Ф.Әмирхан. *Мәҗит Зәйнуллин – һәртөрле иҗади идеяләр белән янып йөрүче, мавыгучан, фанатик кеше.* Ватаным Татарстан

**ФАНА́ТИКЛАРЧА** *рәв.* **1.** Фанатикларга хас булганча, фанатиклык сыйфатларын алып. *Бертай әкә улының джаз белән фанатикларча мавыгуын өнәп бетерми.* Р.Мирхәйдәров. *Үземә куплап өелгән партия порученияләрен алны-ялны белмичә, фанатикларча үтәргә тырыштым.* Ф.Садриев

**2.** *с. мәгъ.* Фанатиклар сыман, фанатикларга охшаган. *Дөньяда үз эшенә*

*фанатикларча гашыйк кешеләр генә бәхетле була ала.* М.Мәһдиев. *Фанатикларча диндар француз кызы Луиза Латонның чиркәүдә, Гайса газаплары көнен бәйрәм иткәндә, аяк-куллары кадакланган пәйгамбәрнең җәрәхәт урыннарындагы кебек канлы яралар барлыкка килгән.* Кызыклы психология

**ФАНА́ТИКЛЫК** *и.* Фанатик булу. *Бу әфәнденең [Геббельсның] фюрерга чамадан тыш ышануы һәм табынуы менә – хак фанатиклык, акылга байлыктан яралмый бугай.* Т.Әйди

**ФАНАТЛА́РЧА** *рәв. к.* **фанатикларча**. *Аларны [эчтәлекле әңгәмәләрне] Револен кебек Советлар властена фанатларча инанган партия һәм совет органнары җитәкчеләре, депутатлар, активистлар үткәрделәр.* К.Латыйп

**ФАНЕР** *и. нем.* **1.** Агачны ярып эшләнгән юка пластиналарны бер рәт аркылыга, бер рәт буйга кат-кат ябыштырып әзерләнгән төзелеш материалы. *Яшел Үзән заводыннан --- фанер, пластмасса, идәнгә җәяргә паркетлар да алып килгәннәр иде.* Г.Ахунов. *Фанердан бүлеп эшләнгән, бер үк вакытта кухня булып та саналган бу тар гына аралык ут янмаганга караңгы иде.* Г.Минский

**2.** *с. мәгъ.* Шул материалдан эшләнгән, шул материалдан торган. *Киндер алъяпкычлы берәү, кереп, тәрәзәнең коелган пыялалары урынына фанер такта кадакларга тотынды.* А.Алиш. *Һәм, чыннан да, март азакларында укытучылыктан сөрелгән әти, сары төстәге зур фанер чемоданын өстерәп, яңадан өйгә кайтып керде.* А.Расих

**ФАНЕ́РА** *и. нем. кит. к.* **фанер**. *Төнлә белән юлда безне узып киткән йөк машинасыннан төшеп калган берничә фанера кисәген алып салган идек.* Г.Наис

**ФА́НЗА** *и. кыт.* Кытайда, Кореяда ярлы крестьян өе. *Чжу карт фанзасы да тышкы күренеше белән мондагы тәбәнәк балчык фанзалардан бернәрсәсе белән дә аерылып тормый иде.* А.Шамов. *Кечкенә фанзаларның түбәләре камыш, салам яисә каралып беткән чүлмәк белән ябылган.* Р.Мостафин

**ФАНИ** *с. гар.* 1) Тиз уза, үзгәрә торган, кыска вакытлы. *Кулымны селтәдем фани җиһаннан, авызда папирос, алдымда сыра.* Г.Тукай

2) Дөньяви, ахирәткә капма-каршы буларак, бу дөньяга караган, бу дөнья белән бәйле булган. *Сез фани дөнья өчен ата-ана күңелен рәнҗетүдән курыкмыйсыз.* Ф.Әмирхан. *Ихтимал, бик сирәк очракларда гына аерым кеше, ниндидер фани исәпләрдән чыгып, «исемен» үзгәрткәндер.* Ә.Еники

◊ **Фани дөньядан бакый дөньяга күчү** Үлү, вафат булу. *Мөселманнарда үлү юк бит ул, күчү генә бар – фани дөньядан бакый дөньяга күчү бар.* Г.Гыйльманов

**ФАНИЛЫК** *и.* 1) Фани (*1 мәгъ.*) булу, вакытлы, уза торган булу. *Дөньяның фанилыгына ышанмыйча, якын кешесенең каберенә көн саен килеп, сәгатьләр буе тере кеше белән сөйләшкәндәй елап утыручылар.* Н.Гариф. *Ә яшәеш барыбер фанилыктан бакыйлыкка таба хәрәкәт итә.* Н.Сафина

2) Бу дөнья. *Фанилык белән мәңгелек арасында өзлексез кыйралыш барган.* М.Кәрим. *Ширияздан ага Сарымсаков, Бату ага Мөлековлар, фанилыкны калдырып, бакый дөньяга күчтеләр.* Казан утлары

**ФАНТ** *и. нем.* 1) Шобага салынган әйберләрдән кемнең әйбере килеп чыкса, шул кеше башкалар кушкан берәр эшне үтәүдән гыйбарәт җырлы-биюле уен. *Уеннардан «Фант», «Ватык телефон», «Күперле», «Йөзек салыш», «Өчле бию»дә актив катнашты алар.* Заман сулышы

2) Шул уенда катнашучылардан шобага салу өчен алынган әйбер. *Фантны, гадәттә, уен шартын үти алмаган кешедән алалар.* Җырлы-биюле уеннар. *Уенның шарты буенча, егеттән фант алырга тиеш иделәр.* Казан утлары

3) Шул уенда шобагасы чыккан кешегә кушылган эш

**ФА́НТА** *и. нем.* Гадәттә әфлисун тәме килеп торган газлы эчемлек. *Нимеснең аларны сатып алырга мөмкинлеге дә җитә, әмма ул кока-кола, пепсикола, фанта, сыра белән әвәрә килә.* Т.Әйди. *--- директор зур канәгатьлек белән өстәлдәге бокалларны тутырып салды. Килешүне шулай фанта белән беркетеп куйгач, бүлмәдә яңадан Миләүшә пәйда булды.* И.Сәйфуллин

**ФАНТАЗЁР** *и. рус* 1) Хыялый, тормышка ашмаслык хыяллар белән яшәүче кеше. *Менә укы. Болар да фантазёрлармы?* Р.Ишморат

2) Уйдырма, дөрес булмаган, үзе уйлап чыгарган сүзләр сөйләүче кеше. *Ай-яй, шәп фантазёр икәнсең син, егет, ә бит Чувашиядә андый ГЭС бөтенләй юк.* В.Нуруллин

**ФАНТАЗЁРКА** *и. рус* Фантазёр хатын-кыз. *Юкны сөйләмә инде, фантазёрка.* Т.Галиуллин

**ФАНТА́ЗИЯ** *и. гр.* 1) Гаҗәеп уйлап табуларга сәләтлелек, фикерләү киңлеге. *Халыкның --- киң фантазиясеннән туган бер хикәядер.* Г.Тукай. *Юмартның фантазиясе бай түгел, хәзиндә ни бар, шуны бирә ул сиңа. Ләкин саранның фантазиясе – төпсез упкын.* М.Мәһдиев

2) Буш, коры хыял. *Бәлки вак милекченең фантазиясен генә сыйдыра алырлык икенче бер хыял катышу хисе бар.* Г.Нигъмәти. *Әйтергә кирәк, йөгәнсез фантазия.* Г.Бәширов

3) Уйдырма, тормышта булмаган гаҗәеп хәлләр, эшләр. *Ул чакның тук һәм тыныч шартларында, тулаем тормыш көн саен гел яхшыга үзгәреп торганда, бу [зур дөнья сугышы кабыну хакындагы] куркынычлар фантазия генә булып тоелса, менә хәзер инде без шуларның реаль гәүдәләнеш ала баруына шаһит булдык.* З.Мифтахов

4) Буш сүз, имеш-мимеш. *Кайчагында Газиз абыйлар өендә куян пилмәне ашап, әчеткән бал белән сыйланганнан соң, Шакай белән Газиз, кәефләнгән хәлдә мәдрәсәгә кереп, куян ату вакыйгаларын әллә нинди фантазия һәм ялганнар катыштырып сөйлиләр.* Ш.Камал. *Бәлкем, чыннан да, Казан хәзинәсе турындагы хәбәр-язмалар фантазия җимеше генәдер, бәлкем, ул бөтенләй булмагандыр.* Сөембикә

5) Хыялда гына булырга мөмкин, сөйләп аңлатып бетерә алмаслык хәл, вакыйга, халәт. *Кайнар аш, куе чәй дигәнең җәннәт сые, фантазия иде.* Б.Камалов

6) *муз.* Иректә формада язылган музыкаль әсәр, экспромт, импровизация. *Аның иң беренче музыкаль әсәре, мәсәлән, ике казах халык көенә нигезләнеп язылган фортепиано өчен фантазия.* Безнең гәҗит

**ФАНТА́ЗИЯЛЕ** *с.* Фантазиягә бай, хыялый. *Сөйли алмас аның шаушуларын фантазияле әкият остасы.* Ш.Мөхәммәдев

**ФАНТАСМАГО́РИЯ** *и. фр.* 1) Кешенең төрле халәтендә күз алдына килгән әкәмәт күренешләр. *--- акылына зыян килгән кеше тарафыннан күрелгән күренешкә охшаган фантасмагория – В.Якимовның «Тәрәгә кадакланырга ашкынучылар» картинасына, сюрреализм стиле И.Хановның*

*«Җәбраил» әсәренә хас.* К.Гыйззәтов. *Менә шушылардан [реаль чынбарлык һәм автор фантазиясе аша] еш кына төрле балкыштагы гаҗәеп фантасмагория барлыкка килә.* Казан утлары

2) *иск.* Оптик җайланмалар ярдәмендә тудырылган фантастик шәүләләр

3) *күч.* Юк-бар идеяләр, буш фантазияләр. *Катып калган фикер һәм авторитетларны аллалаштыру нәтиҗәсе булган фантасмагория иде бу.* Р.Хәкимов

**ФАНТАСТ** *и. гр.* 1) Фантазиягә бай, хыялланырга яратучы кеше. *Шундый чакта син – тылсымчы, кыю фантаст. Йөрәгең аша чор-гасырлар эфир булып исә. Син балаң гасырында.* Р.Харис

2) Фантастик әсәрләр язучы. *Бөтенләй башка телдә укып «кеше булган» дөнья күләмендә данлыклы вулконолог Һарун Таҗиев, галим, әдип-фантаст Айзек Әҗимов, дөнья балеты сәнгатен яңа баскычка күтәргән Ковент-Гарден король балетының балетмейстеры Рудольф Нуриевлар турында татар халкы әле шушы көнгә кадәр хәбәрдар түгел диярлек.* М.Юныс. *Америка фантасты Р.Хайлапны ФБРга чакыртып сорау алалар.* Кызыклар дөньясында

**ФАНТА́СТИК** *с.* 1) Фантастика өлкәсеннән, фантастикага нигезләнгән. *Авыз-шигырь иҗатының фантастик геройлары Тукай уенда да калмый ияреп йөриләр.* Г.Нигъмәти. *Юк, нигә бу космос турында фантастик кинолар төшерүче режиссёрлар безнең авылга килеп китмәделәр икән?* И.Сирматов

2) Бик гаҗәп, әкәмәт, тылсымлы, хыял белән күпертелгән. *Күп кенә легендаларның нигезендә чыннан да булган, әмма хыял тәэсирендә үзгәртелгән вакыйгалар ята, ә менә бу легенданың сюжеты да, образлары да, фантастик төсмерләре дә юк.* Р.Мостафин. *Ак болытлар океанында – бер әкияттә дә тасвирланмаган әллә нинди фантастик сурәтләр.* Р.Хисмәтуллин

3) Буш, кеше ышанмаслык ялган, уйдырма. *Ләкин, күпмедер вакыт узгач, хәлләр үзгәреп киткәч, әлеге тузга язмаган фантастик гаепләүләр тагын да дәһшәтлерәк булып калкып чыгачак.* Д.Шәрәфетдинов

4) Гаҗәеп, бөек, грандиоз. *Кыйссада сәүдәгәр хезмәте авыр, хәтәр, әмма мавыктыргыч, маҗаралы, фантастик табышлы кәсеп итеп күрсәтелә.* Татар әдәбияты тарихы. *Фантастик планнар*

5) Гаҗәеп күп, исәпсез. *Әсирлеккә үз ирege белән төште, дип теркикме? --- югыйсә әсирләр бик күп, фантастик санда күп, барысына да ашамлык җиткерә, тиешле табиблык ярдәме күрсәтә алмыйбыз.* Т.Әйди

**ФАНТА́СТИКА** *и. гр.* **1.** 1) Әдәбият, кино, рәсем һ.б.ш. сәнгать төрләрендә чынбарлыкны хыялый җирлектә сурәтләгән иҗат алымы. *Вагнерда, чыннан да, фантастика күп, композитор легендаларга таянырга ярата.* Т.Әйди

2) Буш, коры хыял, уйдырма. *Бу фантастика түгел, версия, ә ул тәҗрибәгә килеп бәйләнә.* Р.Мөхәммәтҗанов

**2.** *ы. мәгъ.* Гаҗәпләнүне, хәйран калуны белдерә. *Фантастика, зур шәһәрдә аны көндез чыра яндырып эзләсәң дә таба алмыйсың, ә биредә – кемгә кирәк ул?* Р.Мирхәйдәров

**ФАНТА́СТИКЛЫК** *и.* Фантастик булу

**ФАНТОМ** I *и. гр. кит.* 1) Гадәттә кеше хыялында тудырылган гаҗәеп куркыныч күренеш, өрәк. *Мәрхүмнәргә охшаш кешеләр фантом, өрәк рәвешендә уйламаганда күз алдына килеп басарга мөмкиннәр.* Татарстан яшьләре

2) *мед.* Күрсәткеч әсбап буларак кулланылган, табигый зурлыктагы кеше гәүдәсе яки аның аерым әгъзалары модельләре

3) Шул исемдәге маркалы Америка хәрби истребитель очкычы. *Шулай да кайбер очракларда бик нык коралланган «Фантом» бомбардировщиклары Төньяк Вьетнамның башкаласы Ханойга кадәр үтеп керәләр.* Р.Ибраһимов

**ФАНТОМ** II *с.* 1) *физиол.* Күзалланган, уйдырма, ялган. *Британия утрауларында кайберәүләр әле дә булса колонияләр «өзелеп калудан» туган «фантом чирләр» белән авыргалыйлар, диләр.* Н.Шәрифуллин

2) *мед.* Күргәзмә әсбап хезмәтен үтәгән. *Фантом әгъза*

3) Ясалма. *Фантом электр чылбыры*

**ФАНУС** *и. гар.* Маяк, фонарь. *Фәрхәд кебек, «мөһәндисләр сизмәгән җирдән казып», «әнһарел-хаканкны» агыза; Данко шикелле, «караңгыда фанусны кабыза».* Татар әдәбияты тарихы

**ФАНФА́РА** *и. ит. муз.* Тантананың башлануын хәбәр итә торган музыкаль фраза, сигнал һәм шул сигналларны уйный торган озын җиз торбалы, тынлы уен коралы. *Быргычылар быргы уйный, яңгырый фанфаралар.* Г.Хуҗиев. *Фәрештәләр бии фанфарага – туктар микән бу туй өч көннән?!* З.Мансуров

**ФАНФА́РАЧЫ** *и.* Фанфарада уйнаучы

**ФАР** *и. фр.* Транспортның алгы (кайчакта арткы) өлешенә юлны яктырту өчен урнаштырылган яктылык чыганагы һәм аны чагылдыргыч батынкы көзгедән гыйбарәт фонарь. *Тракторның фарлары яктырта кырда парлап.* Р.Харис. *Сары машина фарында, җилкапка шыгырдавында, көз сары яфраклардан иңгән хәтердәге исемнәр кебек.* С.Гәрәева

**ФА́РА** *и. фр. к.* **фар**. *Караңгылык куера башлап, тырма эзләре күренмәс булганнан соң, Гөлсем трактор фараларын яктыртып җибәрде.* Г.Бәширов. *Судан күтәрелүче томан катыш машина тәтененнән тоташ зәңгәр чаршау барлыкка килә, гигант баганалар сыман, фара утлары чайкала.* Р.Мостафин

**ФАРАЗ** *и. гар.* 1) Ният, уй, фикер. *Ул яңа мәдрәсәле бер шәһәргә барып керде дә, үзе шунда торып, «читтән тыңлаучы» сыйфаты илә дәресләргә йөргәләргә керешә һәм атасына Мысыр һәм Гарәбстан ягына китү фаразы барлыгын язды.* Г.Ибраһимов

2) Чама, исәп, гипотеза. *Хыянәттән, тугрылыксызлыктан шикләнгән күңел әллә нинди сурәтләр, фаразлар тудыра иде.* Ф.Латыйфи

**ФА́РАЗАН** *кер. сүз гар.* 1) Әйтик, ягъни мәсәлән, уйлап караганда. *Кайдан алып кайттыгыз, фаразан, шунда илтеп куегыз.* Ф.Әмирхан. *Җитәр инде, фаразан, күп сөйләп торма.* Ш.Камал

2) Мөгаен. *Ә анысы минем хата булган, фаразан.* Ш.Камал

**ФАРА́З ИТҮ** *ф.* **1.** Уйлау, исәпләү, чамалау. *Фараз итегез, тәңренең үзеннән әмер килде.* Г.Ибраһимов. *Мин исә үзем белгән чалмалы мулла күрермен дип фараз иткәнмендер.* А.Расих

**2. фараз иттек** *кер. сүз мәгъ.* Мәсәлән, ягъни мәсәлән, фаразан. *Шәһәрдә, фараз иттек, кунакларны кыстату бөтенләй юк иде.* Ш.Камал

**ФАРА́З КЫЛУ** *ф. к.* **фараз итү**. *Ә, ягъни мәсәлән, фараз кылдык, бозавы ни хәлдә, бозавы?* К.Тинчурин. *Китте шикләнү, китте юраулар, фараз кылулар, күрәзәлек, табышмак чишүләр.* А.Гыйләҗев. *Эш җан саклауда гына да түгел, бәлки аларның монда ышаныч казануы татарның гомум язмышына да уңай тәэсир итәр, дип фараз кылды.* Т.Әйди

**ФАРАЗЛА́У** *ф.* Фараз итү, уйлау, исәпләү. *Тормыш дәреслегеннән этәрелеп, киләчәкне фаразлау.* Ф.Галимуллин. *Бераз кәефе кырыла төшкән булса да, аны-моны сиздермәде, төшен үзенчә фаразлады.* Н.Хәсәнов

**ФАРАЗЛАУЧЫ** *с.* Фараз итүче, уйлаучы, исәпләүче; алдан күрүче, интуицияле. *Киләчәкне фаразлаучы галимнәр узган гасырның җитмешенче елларында ук инде, фәнни алымнарга нигезләнеп, моңарчы күрелмәгән зур дөнья сугышы кабыну ихтималы турында сөйли башлаганнар иде.* З.Мифтахов

**ФАРВА́ТЕР** *и. голл. махс.* Суднолар йөрү өчен маяк куелган куркынычсыз су юлы. *Дөньяның теләсә нинди океаннарында һәм диңгезләрендә рәхәтләнеп йөрүче безнең гүзәл «Җәлил»ебез портның бу тар фарватерында үзен бик кысан тоя.* Р.Мостафин. *Судно куркынычлы фарватердан бара, ул [капитан], күперчекне калдырып китә алмыйм, ди.* М.Юныс

**ФАРИНГИТ** *и. гр. мед.* Тамак төбе ялкынсыну. *Ангина, фарингит булганда, бүлмә температурасындагы суда берәр чеметем куркума һәм тозны эретеп, тәүлегенә дүрт тапкыр авызны чайкыйлар.* Мәдәни җомга

**ФАРИНГОСКОПИ́Я** *и. гр. мед.* Махсус көзгеләр ярдәмендә тамак төбен һәм йоткылыкны карап тикшерү

**ФАРИНГОСПАЗМ** *и. гр. мед.* Йоткылык мускулларының кискен, спазм рәвешендә кыскаруы (мәс., истерия вакытында)

**ФАРИСЕЙ** *и. гр.* 1) Фарисейлык тарафдары. *Иудеядәге күп секталар арасында безнең эрага хәтле I гасырдан безнең эраның II гасырына хәтле бигрәк тә өч иҗтимагый дини тармак киң таралган була: фарисейлар, саддукейлар һәм ессейлар.* А.Муранов

2) *күч.* Икейөзле, эчкерле кеше. *Кайгы сезгә, канунчылар һәм фарисейлар! Монафикълар! Сез – агартылган төрбәләр кебек: тыштан матур ---.* Р.Сафин

**ФАРИСЕЙЛАНУ** *ф.* Икейөзлеләнү

**ФАРИСЕЙЛА́РЧА** *рәв.* **1.** Фарисейлар сыман, фарисейларга хас булганча. *Барысы да фарисейларча ясалып, ак җепләре күренеп торган итеп эшләнде.* Ф.Хөсни. *--- урыс авылының көтүен көткән шагыйрьне иҗат командировкасыннан кайткандай итеп күрсәтүгә гаҗәп-хәйран калмыйча мөмкин түгел. Бу хәтле дә фарисейларча ялганлап маташу кемгә, ни өчен кирәк булды икән?!* Ә.Еники

**2.** *с. мәгъ.* Фарисейларга хас булган, фарисейлар кебек, икейөзле. *Бу – партияне һәм эшчеләр сыйныфын алдауга исәпләнгән ялган, фарисейларча платформа иде.* КПСС тарихы

**ФАРИСЕЙЛЫК** *и.* 1) *дини тар.* Борынгы Яһүдиядә үзләренең монафикълыгы белән аерылып торган шәһәр байлары яклаган дини-сәяси юнәлеш

2) *күч.* Икейөзлелек, монафикълык

**ФАРМАЗОН** *и. пол. иск.* Сәер холыклы, үзен тотышы яшәп килгән карашларга, тәртипләргә туры килми торган кеше

**ФАРМАЗОНЧЫ** *и.* Аферист, алдау-йолдау белән көн күрүче. *Үзе гаҗәп оста фармазончы: кешене күз алдында алдый белә.* З.Фәтхетдинов

**ФАРМАКОГЕНЕ́ТИКА** *и. гр. мед.* Даруларга организм реакциясенең генетик нигезләрен өйрәнә торган медицина генетикасы бүлеге

**ФАРМАКОГНО́ЗИЯ** *и. гр.* Дару ясарга яраклы хайван һәм үсемлек материалларын өйрәнә торган фән. *Фармакогнозия курсын оештырып, берничә ел аның җитәкчесе булып эшли.* Фәнни Татарстан

**ФАРМАКОДИНА́МИКА** *и. гр. мед.* Дару матдәләренең организмга йогынтысы механизмын, эффектлылыгын өйрәнә торган фармакология фәне бүлеге

**ФАРМАКОКИНЕ́ТИКА** *и. гр. мед.* Даруларның организмга үтеп кергәннән соң таралуын, метаболизмын һәм чыгарылуын өйрәнә торган фармакология фәне бүлеге

**ФАРМАКО́ЛОГ** *и. рус мед.* Фармакология белән шөгыльләнүче белгеч. *Авыру кешенең даруны кайчан, кайсы сәгатьләрдә кабул итүенең дә әһәмияте бар икән, хәзергә бу мәсьәләдә фармакологларга кайбер нәрсәләр генә мәгълүм әле.* Могҗизалар энциклопедиясе

**ФАРМАКОЛО́ГИК** *с. мед.* Фармакологиягә мөнәсәбәтле, даруның организмга йогынтысына караган. *Даруларның фармакологик тәэсире иммун троплыкка да бәйле.* Фәнни Татарстан

**ФАРМАКОЛО́ГИЯ** *и. гр. мед.* Даруның организмга тәэсирен өйрәнә торган фән. *Фармакология иммунокоррекция препаратлары, гормоннар һәм медиаторлар белән тәэсир итүне дә үз эченә ала.* Фәнни Татарстан. *Экспериментал фармакология*

**ФАРМАКОМПА́НИЯ** *и. гр. мед.* 1) Авыруның төрле даруларны яисә нинди дә булса бер даруны кабул итәргә омтылышы

2) Дарулар белән гадәттән тыш артык мавыгу, даруларны кирәгеннән артык куллану

**ФАРМАКОПЕ́Я** *и. гр. мед.* Даруларны әзерләү, саклау, тикшерү алымнары, дозалары, аптекада дару ясау өчен чимал буларак сакланырга тиешле материалларның исемлеге күрсәтелгән рәсми кулланма

**ФАРМАКОТЕРАПИ́Я** *и. гр.* Авыруларны дарулар ярдәмендә дәвалау ысуллары җыелмасы

**ФАРМАКОХИ́МИЯ** *и. гр.* Фармацевтик химия: даруларның химик һәм физик үзлекләрен, шулай ук аларны ясау методларын һәм сыйфатын өйрәнә торган фән

**ФАРМАЦЕВТ** *и. рус мед.* Махсус белемле дару ясаучы. *--- табиб, фармацевт һәм повар белгечлекләре Кытайда бер-берсеннән әллә ни аерылмый.* Татарстан яшьләре

**ФАРМАЦЕ́ВТИК** *с.* Фармацевтикага караган. *Фармацевтик оешмаларның яңа антимикроб матдәләр эзләү һәм җитештерүгә кызыксынуы кимү авыр дәвалана торган инфекцияләр саны артуга китергән факторларның берсе булып тора.* Фән һәм тел

**ФАРМАЦЕ́ВТИКА** *и. гр. мед.* Даруларны ясау, эшкәртү, саклау турындагы фәнни дисциплина. *Ә ул фармацевтика лабораториясе дә ачты.* И.Гази. *Шул сәбәпле фармацевтиканың 70 процентын чит ил препаратлары тәшкил итә иде.* Сөембикә

**ФАРМА́ЦИЯ** *и. гр.* Фәнни белемнәрнең һәм практик эшчәнлекнең даруларны саклау, сыйфатларын тикшерү, аларны җитештерү белән шөгыльләнә торган тармагы. *Илдә үзгәртеп кору башлангач, чит ил фармациясенә Россия базарында юл ачылды.* Сөембикә

**ФАРМИНДУСТРИ́Я** *и. рус к.* **фармация**. *Икенче яктан, кризис, үсү өчен, Россия фарминдустриясенә уңай этәргеч ясады.* Сөембикә

**ФАРС** *и. лат.* 1) Көнбатыш Европада урам халык театрының көнкүреш-сатира эчтәлекле төре. *Әлеге әсәр – большевиклар хакимиятенең --- аянычлы хәлен фарс рәвешендә ачып бирү омтылышы.* Ф.Галимуллин

2) XIX–XX йөзләрдә җиңел эчтәлекле комедия, водевиль. *Бу авыру*

*басылыр-басылмас торганда, үткән сезоннан башлап, --- фарслар сериясе дөньяны каплап алды.* Ф.Бурнаш

3) *күч.* Тупас шаяру, шамакайлану. *Милләтнең көче кая сарыф ителгәнен болгарчылар мисалында күп елларга сузылган мәгълүм фарс ачык күрсәтә.* Р.Хәким

**ФАРСИЗМ** *и. рус лингв.* Телгә фарсы теленнән кергән сүз яки гыйбарә. *Бу телләр лексикасында очрый торган аермалар, башлыча, күрше халыклар теленнән күчкән алынмаларга, төрле тамырдан ясалган сүзләргә, төп сүзлек составына кергән арабизм һәм фарсизмнарның азмы яки күпме булуына гына бәйле.* Ә.Кәримуллин

**ФАРСЫ** *и.* Телләре һинд-европа семьясының иран телләре төркеменә караган, мөселман динен тота торган, Иранда яшәүче төп халык атамасы (үзатамалары – *ирани*) һәм шул халыкның бер вәкиле. *Фарсы мифологиясендә кеше тумышы Күк-Табигать белән чагыштырыла.* Г.Гыйльманов. *Иран халкының яртысы чамасы – фарсылар.* Чит илләрнең экономик географиясе

**ФАРСЫ́ЧА** *рәв.* **1.** Фарсы телендә. *Попугай сүзен тәмам кылгач --- бүдәнә, мәйданга чыгып, фарсыча сөйли башлады.* Ш.Мөхәммәдев. *Төркестан якларында күп йөргән Фатих алар белән фарсыча сөйләп җибәрде.* Ш.Усманов

**2.** *с. мәгъ.* Фарсы телендәге. *Кәләпүш – фарсыча сүз: кәлә – «баш» мәгънәсендә, пүш – «япмак» мәгънәсендә; «баш капкачы» дигән кебек була.* К.Насыйри. *Миннән фарсыча игъланны ятътан укыта иде.* М.Галәү

**ФАРТ** *и. нем.* Уңыш, бәхет. *Акмал әкәне, бәлки, демократия йөгәнсезлегендә җәфа күргән кеше дип, төрмәдән дә коткарырлар, пенсия дә билгеләрләр, әмма моннан ни фарт – акчасыз, досьеларсыз, тән сакчыларысыз ул инде хан түгел дә түгел!* Р.Мирхәйдәров

◊ **Фарт килү** Бәхеткә туры килү, уңай килү, эш уңу. *Фарт килсәме? Фарт килсә, бер сәгать эчендә купис буласың.* Г.Бәширов. **Фарт чыгу** Бәхеткә ирешү, теләкләр үтәлү. *– Мин байтак җирләрдә булдым, – диде ул, – тик миңа фарт кына чыкмады.* А.Расих

**ФАРТЛЫ** *с.* Бәхетле. *Үтте, юнкер, фартлы заманың, кызыл валет яба даманы.* Х.Туфан. *Юлың җиңел булды, шухыр-мухырсыз, фартлы егет син.* Р.Мирхәйдәров

**ФАРФОР** *и. фар.* **1.** 1) Савыт-саба ясау өчен әзерләнгән югары сортлы ак балчыкка (каолинга) өстәмә материаллар кушып ясалган катнашма. *Төрледән-төрле товар, әфлисун-лимон арасында, фарфордан, пыяладан, яшел лак йөгерткән кызыл балчыктан ясалган савыт-саба бихисап булыр иде.* Р.Мостафин. *Чехия бик күптәннән инде югары сыйфатлы графиты һәм фарфор җитештерү өчен кирәкле үзле балчык – каолины белән дан тота.* Чит илләрнең экономик географиясе

2) Шул материалдан ясалган әйбер, савыт-саба. *Фарфор һәм фаянс залларында гарәп сүзләре, гарәп җөмләләре белән бизәлгән Иран савыт-сабалары музейчыларны үзләренә тарталар.* Г.Гобәй. *Венеция пыялалары да, Кузнецов фарфоры да, җил сибереп алгандай, юкка чыга торды.* Р.Мирхәйдәров

**2.** *с. мәгъ.* Шул материалдан ясалган. *Мәскәү күргәзмәсендә Саимәгә --- фарфор чынаяклар бүләк иттеләр.* М.Мәһдиев. *Пионино өсләренә тезеп куелган фарфор сыннарны, бәллүр вазаларны тамаша кылды.* Т.Әйди

**ФАРШ** *и. фр. махс.* Бертөрле массага әйләнгәнче тапалган яки иттарткыч аша үткәрелгән ит, балык яки яшелчә. *Пәрәмәч өчен фаршны симез сыер яки сарык итеннән ясыйлар.* Ю.Әхмәтҗанов. *Баклажан телемнәренә кайнар килеш яшелчә фаршы өеп чыгыгыз.* Сөембикә

◊ **Фарш ясау** *гади сөйл.* Бик нык кыйнап ташлау. *Үзеңнән фарш ясамасыннар, малай.* А.Гыйләҗев

**ФА́РШЛАУ** *ф.* Эченә фарш тутырып пешерү. *Татлы борычны --- ит, дөге, кишер белән фаршлыйлар, үсемлек маенда томалап пешерәләр.* Бакчачы, яшелчәче һәм умартачы календаре

**ФАРЫЗ** *и. гар.* **1.** 1) *дини* Шәригать хөкемнәре арасында мөселманнар өчен үтәлүе мәҗбүри, үтәлмәве гөнаһ саналган эш, гамәл. --- *иман шартындагы кырык фарызны ятлаудан да авыр булды.* М.Гафури. *Бетте, бетте, [намазның] фарызын укып бетердем, Алла кабул итсен.* Г.Бәширов

2) *күч.* Үтәлүе мәҗбүри гамәл, бурыч. *Бу эш хакында Җаббар үз өстенә йөкләтелгән бер фарыз шикелле итеп тырышты.* Г.Ибраһимов. *Кытай халкында йөз тоту – байлар өчен дә, ярлылар өчен дә бердәй фарыз.* Г.Ахунов

**2.** *с. мәгъ.* Шәригатьтә үтәлүе мәҗбүри булган, үтәлмәве гөнаһ саналган (эш, гыйбадәт һ.б.ш.). --- *фарыз гамәлләрне үтәргә кирәк.* М.Гафури

**3.** *хәб. функ.* Тиеш, мәҗбүр. *Дәүләт илә, Үзбәк ханымыз төсле, әмирләр вә бәкләр берлә киңәшләшеп, кумәкләшеп идарә кылу фарыз.* В.Имамов. *Аның [Ибраһим Салаховның] тавышын ишетү безнең яшьләребезнең һәрберсенә фарыз.* Б.Рәхимова

◊ **Фарызын гына үтәү** Эшне өстәнөстән генә башкару, формаль якларына гына игътибар итү

**ФАРЫЗЛЫК** *и.* Фарыз булу, мәҗбүрилек. *Тәһарәтнең фарызлыгына дәлил нәрсә?* М.Гафури

**ФАСАД** *и. фр.* Бинаның тышкы алгы ягы. *Йортның фасадын һәм машиналар кую өчен билгеләнгән мәйданын икенче якка ясагыз.* Г.Ахунов. *Авыр сугыш еллары --- менә шушы таш йортларга да тирән эз салып калдырган: фасадларының төсләре уңган, штукатуралары кубып-кубып төшкән.* Ә.Еники

**ФАСИКЪ** *и. гар.* **1.** 1) *дини* Аллаһның әмерләренә буйсынмаган, ләкин үзенең мөселманлыгын таныган гөнаһкяр кеше

2) Азгын, әхлагы бозык кеше. *Һәр билсез, кыска киемлене дә фасикъ, азгын дип хөкем итәргә тиеш түгелдер.* Г.Тукай. *Габделгазиз – Казанның мәшһүр бай угылы, фасикъ, вөҗдансыз, әхлаксыз, фисыкны мәсләк иткән егет.* Г.Исхакый

**2.** *с. мәгъ.* Бозык, азгын. *Бик күп фасикъ муллалар аның акчасына донос кантурлары ачтылар.* Г.Исхакый. *Ах син, фасикъ җан, яшь хуҗабикәм артыннан сөйрәлдеңме?* Ф.Латыйфи

**ФАСИКЪЛЫК** *и.* Фасикъ булу. *Закирның бу әхлаксызлыклары, бу тәрбиясезлекләре, бу фасикълыклары – бар да Җәмилә абыстайдан, бар да аның бала тәрбия кыла алмавыннан.* Г.Камал

**ФА́СКА** *и. фр.* Берәр нәрсәнең кыеклап киселгән кырые, кабыргасы; кискечләрнең үткен кыры, чарланган йөзе. *Гадәти киң кайракта фаскасы туры почмаклы булган ялгау пычакларын һәм секаторның бер фаскалы кискеч пластинкасын кайрыйлар.* Бакчачы, яшелчәче һәм умартачы календаре

**ФА́СКАЛЫ** *с.* Фаскасы булган. *Пычакның фаскалы ягын әйбәтләп кайрагач, әйләндереп, аскы ягын тигезләп алалар.* Бакчачы, яшелчәче һәм умартачы календаре. *Фаскалы көзге*

**ФАСО́ВЩИК** *и. рус* Нәрсәне дә булса үлчәп тутырып, төреп торучы

эшче. *Кибетләргә, һәрвакыттагыча, грузчик, фасовщик, ягъни үлчәп төрүче кирәк.* Шәһри Казан

**ФАСО́ВЩИЦА** *и. рус* Хатын-кыз фасовщик. *Рабига --- фасовщица булып эшли башлады.* Э.Касыймов

**ФАСОЛЬ** *и. гр. бот.* Кузаклылар семьялыгыннан ак, кызыл, шәмәхә төсле чәчәкле, туры яки үрмәләп үсә торган берьеллык үлән үсемлек һәм аның орлыгы, борчагы, шулай ук кузагы. *Кырларда исә кукурузга үрелеп фасоль үсә.* Кызыклы география. *Ризык әзерләгәндә төрекләр фасоль борчагын күп һәм еш кулланалар.* Казан утлары

**ФАСОН** *и. фр.* 1) Өс һәм аяк киемнәре тегү өчен мода үрнәге, модель, өлге. *Минә шул материядән үземә кием өчен фасон эзлидер идем.* Ф.Сәйфи-Казанлы. *Мәскәүдәге туганнары биреп җибәргән иске күлмәкләрне әүвәл сүтеп ташлый – өлгеләрен ала, фасоннарын өйрәнә дә, соңрак шундый итеп күлмәк тегә.* Р.Камалетдинова

2) *күч.* Тышкы кыяфәт, килешкилбәт. *Вагон тәрәзәсеннән карау белән, ярым немец, ярым француз фасонында Латвия солдатлары күренәләр.* Г.Гобәй. *Егет алар: фасон шәп, төрле фәннән ора гәп.* Г.Кутуй

3) *күч.* Билгеле бер рәвеш, форма, тәртип. *Зур услуга күрсәткән фасон белән нарком иптәшләргә илтеп бирде.* Г.Гали. *Большевиклар яңа фасон чыгарганнар.* Г.Бәширов

◊ **Фасон китерү** *к.* **фасон саклау**. *Фасонын тәмам китерер өчен, ул ап-ак кульяулыгын чыгарып, болай да чиста пыялаларын сөрткән булды.* Т.Әйди. **Фасон өчен** Купшылык, көязлек, тышкы кыяфәт өчен. *Сөйсәң дә болай гына, өстән-өстән генә... фасон өчен... вакыт уздыру өчен генә сөй.* Р.Ишморат. **Фасон саклау** 1) Модалы киенү, һәрвакыт модага ияреп бару; 2) Бөтен таләпләренә туры китереп үз-үзеңне тоту; сер бирмәү. **Фасон тоту** *сөйл.* Кәттә кылану, эреләнү, тәкәбберләнү. *Фасон тотып маташмый, ягъни директор икәнлеген белдереп тору кайгысыннан азат.* Ә.Еники

**ФАСОНЛЫ** *с.* **1.** 1) Модага туры килгән, модалы, яңа модель, өлге белән тегелгән, эшләнгән. *Тик минә манекеннарның фасонлы киемнәрне төнлә күрсәтүе гаҗәп.* Н.Гыйматдинова. *Ул итек бик фасонлы иде, аның куныч очларында шнурлары да бар.* А.Расих

2) Билгеле бер форма биреп эшләнгән, калыпка салынган, үрнәк шаблон буенча ясалган. *Цехка килгәч тә тәкъдим ителгән фасонлы кискеч иде ул.* Н.Хәсәнов. *Һәр кичкенә күлне көзге итеп, үз-үземә сокланып, фасонлы замоклы вельветны карап үтәм.* Ш.Шәйдуллин

**2.** *рәв. мәгъ.* Төрле фасон, өлге белән. *Фасонлы кию*

**ФАСО́НЧА** *рәв.* Фасонны саклап, мода таләпләренә туры китереп. --- *шактый фасонча киенгән өс-башыннан аның җитеш тормышта, оста кулда пешеп җитешкән кыз булуы әллә каян күзгә бәрелеп тора иде.* Ә.Еники

**ФАСЫЙЛӘ** *и. гар. иск.* 1) Тәнәфес. *Шул ук минутлык утырышудан соң, биш кенә минутлык фасыйлә ясап, алар бөтен кичә буенча бергә булганнар.* Ф.Әмирхан. *Мәҗлескә фасыйлә бирелә.* М.Гафури

2) *к.* **буфер**. *Казан белән Мәскәү дәүләте арасында фасыйлә Касим (Хан Кирмән) ханлыгы Россиядә ихтиляль (смута) булган чакта исән иде*... Г.Гобәйдуллин

**ФАСЫЛ** *и. гар.* 1) Бүлек, кисәк. *Мин грамматикада «өч токым» дигән гаҗәеп бер фасыл күрдем.* Г.Тукай. *[З.Вәлиди әсәрендә] Хосусан мөәллифнең уйгурлар вә магуллар дәверендәге мәдәният (мәгариф вә әдәбият) турындагы фасыллары тулы вә яхшы язылган.* Г.Шәрәф

2) Ел вакыты, сезон. *Ел тәүлеге дүрт фасылга бүленәдер: яз, җәй, көз, кыш.* Г.Тукай. *Тикшерми яз, көз фасылын, киядер киемнең асылын, белмидер үзенең нәселен безнең бай балалары.* Ш.Мөхәммәдев

3) Сезон, чор, мәүсим, период. *Әмма аннан соңгы дәвердә тарих куласасы төрле фасылда әйләнеш кичерде.* Казан утлары. *Яңа иҗат фасылын театр өр-яңа тамаша – «32 нче март» дигән бик мавыктыргыч исемле спектакль белән ачып җибәрде.* Мәдәни җомга

**ФАТА** *и. гар.* Кәләш өчен юка, җиңел челтәрдән ясалган бөркәнчек. *Табын түрендә ап-ак күлмәк киеп, ап-ак фата бөркәнеп, йөзек кашы шикелле балкып үз туенда утырудан да зур бәхет юктыр шикелле.* В.Нуруллин

**ФАТАЛИЗМ** *и. лат.* Язмышка, тәкъдир кушуына, күрәчәккә ышану. *Аның күп кенә язучыларга чыгарган «хөкем карары»ннан фатализм исе аңкый.* Ф.Зөлкарнәев. *Дәрдемәнднең тарихи процесска мөнәсәбәтендәге фатализм, язмыш фәлсәфәсе аның лирикасындагы төп трагик тонны --- билгели.* Г.Халит

**ФАТАЛИСТ** *и. рус* Күрәчәккә ышанучы, фатализм тарафдары. *Тыштан тыйнак, сабыр, әдәпле, кешегә авыр сүз дә әйтми торган Зәкиҗан агай характерын күрсәтте: инанган хыяллары өчен үзләргә әзер фаталист икәнлеген раслады.* Т.Галиуллин

**ФАТАЛИ́СТИК** *с.* 1) Фатализмга хас, фатализмга караган. *Элекке татар романтик поэзиясендә гадәттә фаталистик планда, тәкъдир һәм язмыш ноктасыннан чагылдырылган «яшәү һәм үлем» шикелле мәңгелек теманы да Бурнаш икенче төрле итеп җырлый.* Г.Халит

2) Тәкъдир кушкан, язмышка буйсынган, күрәчәк

**ФАТАЛИСТЛА́РЧА** *рәв.* Фаталистларга хас итеп, фаталистлар кебек. *Кадрия язмышны фаталистларча аңлый.* А.Әхмәдуллин

**ФАТАЛИСТЛЫК** *и. к.* **фатализм**

**ФАТАЛЬ** *с.* Котылгысыз, тәкъдиргә язылган, язмышта булачак. --- *шулай итеп, аның [Г.Ибраһимовның] каһарманнары фаталь бер көчнең колы булып чыгалар.* Г.Нигъмәти

**ФАТА-МОРГА́НА** *и. ит.* 1) Офыкта барлыкка килә торган катлаулы, тиз үзгәрә торган, гаҗәеп сагым. *Фатаморгана күзәтү*

2) *күч.* Хыялда тудырылган, реаль булмаган дөнья

**ФАТИР** *и. фр.* 1) Милекнең иясе булган хуҗа тарафыннан вакытлыча тәкъдим ителгән бүлмә, почмак, торак. *Инде ике көн булды, фатирга акча бирмисең, дип, самавыр да бирмиләр.* Г.Камал. *Унике сумга бүлмә алып фатирга кердем, шул хак исәбенә хуҗабикә керләремне уа, урын-җирне карый һәм һәр көнне өч тапкыр кайнар аш ашата иде.* А.Расих

2) *сөйл.* Квартир. *Бүгенге көндезгә сәхәр Кәрим фатирында буласы, шунлыктан, ул, иртәдән үк, үзенчә кунаклар каршыларга әзерләнә башлый.* Ф.Әмирхан. *Минһаҗ абзыйның фатиры яхшы җиһазланган: тормыш итәр өчен бөтен мебеле, йорт әсбаплары бар.* Т.Әйди

◊ **Фатирга кертергә була** Размеры туры килмәгән, артык зур, буш, иркен (кием-салым тур.)

**ФАТИРДАШ** *и.* Бер-беренә карата: бер фатирда, бергә яшәүче кешеләр,

өйдәш. *Аның тынгысыз фатирдашы дөрес әйтә шул: кайгы-хәсрәт үз юлыннан, ә тормыш – үз сукмагыннан шул кайгы юлына үрелеп бара бирә.* К.Нәҗми. *Агроном абый фатирдашы Актәпине ишегалдына куып чыгарган да идәнне иңләп-буйлап тартмалар тезгән.* Н.Гыйматдинова

**ФАТИРЧЫ** *и.* 1) Фатирда торучы, квартирант. *Ачлыкка бәйләнешле бары ике эпизод кына хәтердә калган: берсе аның – безнең аскы катта яшәүче фатирчы бабайларда алабута икмәге ашап карау ---.* А.Расих. *Яңа фатирчы – фрау Берна өчен ят бер дөнья, шунлыктан аның белән ныграк кызыксынуы табигый иде.* Т.Әйди

2) Фатир төшерүче, торак хуҗасы. *Фатирчы бер карт руска барып төштек.* Г.Тукай

**ФАТИХА** *и. гар.* 1) Коръәннең беренче сүрәсе. *Намазын ул булдыра алган кадәр тиз тота, сүрәи «Фатиха» янына бик кыска сүрәләр генә куша.* Ф.Әмирхан

2) Руханилар, ата-ана, остаз яки шулар кебек үк якын кешеләрнең рәсми ризалыгы, изге теләктәшлеге, хуплавы, эшнең яки юлның уңышлы тәмамлануы өчен рухи шарт. *Инде, бер-ике адым атлар-атламас, Оренбур өязеннән дә үтә алмый шушы авылда бикләнеп калсам, атамның үзеннән дә, малыннан да, фатихасыннан да ваз кичеп чыгуымның күпме генә әһәмияте кала?* М.Фәйзи. *Ә бит, чыдамлык белән сабырлык – фатихага бәрабәр, дигән китап.* М.Хәсәнов

3) Рөхсәт, хуплау; ризалык, бәхиллек. *Бик озын фатиха биреп, шәкертләрне озатып, яңа тормышка чыгарып җибәрде.* М.Гафури. *Барырга кирәк, кызым, дәү әтиеңнең фатихасын алырга кирәк.* Ә.Еники

◊ **Фатихада булу** Теләп тору, кемгәдер теләктәшлек күрсәтү. *Шулай фатихада бул инде, әби.* М.Фәйзи. **Фатихада тору** *к.* **фатихада булу**. *Фатихада торыгыз инде, хәзрәт.* М.Галәү

**ФАТИХА́ КЫЛУ** *ф.* Кул күтәреп дога кылу. *Ягез, чәйгә фатиха кылыйк.* М.Фәйзи

**ФАТИХАЛА́У** *ф. сир. к.* **фатиха кылу**. *Фәрештәләр фатихалый туры юлга...* Г.Мөхәммәтшин

**Фатихалап җибәрү** Озакка сузмыйча дога кылу, амин тоту. *Я инде алайса, фатихалап та җибәрик.* М.Фәйзи

**ФАТИХАЛЫ** *с.* Фатиха (*2 мәгъ.*) бирелгән, теләктәшлек күрсәтеп рөхсәт ителгән. *Син Сахбуш, юкны сөйлисең, анда фатихалы кеше кирәк.* М.Гафури

**ФАТИХАСЫЗ** *с.* Каргалган, кире кагылган. *Ул фатихасыз егет гомергә изгелек күрмәсен.* М.Гафури

**ФА́УНА** *и. лат.* 1) Борынгы Рим мифологиясендә урман-кыр алиһәсе

2) Аерым территориянең, геологик чорның хайваннар дөньясы. *Ләкин бу чорның үзенең дә фаунасы һәм флорасы барлыкка килгән.* А.Фаткуллин. *Безнең фаунада бу хайваннар отрядының су патшалыгына күчкән бердәнбер вәкиле – ялтыравык су үрмәкүче – бигрәк тә гаҗәп.* Кызыклы физиология

**ФАУНИ́СТИКА** *и. лат. махс.* Аерым территориянең, геологик чорның фаунасын өйрәнә торган фән

**ФАУСТПАТРОН** *и. нем. хәрби* Күтәреп йөрергә мөмкин булган, танк, хәрби ныгытмаларга ата торган, бер кулланылышлы гранатомёт. *Йортлардан, подваллардан, чардаклардан аталар. Аерата фаустпатроннар алга барырга комачаулый, танкларны, тупларны яндыра, урам сугышларында шактый кеше һәлак була иде.* Казан утлары

**ФАХИШ** *с. гар.* **1.** 1) Азгын, бозык, уйнашчы, җенси тотнаксыз

2) Чиктән чыккан, дөреслеккә туры килмәгән. *Фахиш тавыш, фахиш рух, фахиш көй!* Г.Тукай. *--- безнең төбәктәге гади мөселманнар һәртөрле әкиятләрне һәм фахиш уйдырмаларны риваять дип кабул иткәлиләр.* А.Тимергалин

**2.** *и. мәгъ.* 1) Азгын, бозык, уйнашчы, җенси тотнаксыз ир кеше. *Болар – бер сынык икмәк өчен үзләренең нәфис тәннәрен сатып, очраган һәрбер фахишнең кочагына атылырга мәҗбүр булган, Ходаның мәзлум бәндәләре.* Г.Ибраһимов. *Арада угрылар, җан кыючылар, фахишләр, мөртәтләр дә бар иде.* А.Гыйләҗев

2) Дөрес булмаган, дөреслеккә туры килмәгән әйбер. *Бу заман язучыларының хатаи фахишләреннәндер ки, булды урынына улды язалар.* К.Насыйри

**ФАХИШӘ** *и. гар.* Уйнашчы, зиначы хатын. *Бары тик шул бер фахишәне үтереп, үземне гомерлек бер кайгыга, гомерлек бер газапка, гомерлек бер хәсрәткә генә салдым.* Г.Камал. *Бүген, әрсез кызлар иншаларында валютага эшләүче фахишә булырга теләүләрен оялмыйча язган заманда, ул кызыйның хыялы берәүгә дә сәер тоелмас иде.* Р.Мирхәйдәров

**ФАХИШӘЛЕК** *и. к.* **фахишлек**. *Фахишәлеккә, хатын-кызларны сатлык итеп йөртүгә, мыскыллауга да чик куярбыз без.* А.Шамов. *Шулай ук фахишәлек кылып, Закир кебек эшсезлектән йөдәгән бай малайларын алдап йөрүче чая телле Гайни дә, үзенең бозыклыгы ягыннан, Мәгъри карчыктан бер дә калышмый.* М.Гали

**ФАХИШЛЕК** *и.* Фахиш булу. *--- зина, фахишлекләр илә башлары әйләнеп, дөнья-ахирәт бәхетләреннән коры калганнар.* Г.Тукай. *Әйт, Бибкәй, алар үзләре бит дөньядагы барлык кабахәтлекне эчләренә җыйнап, халык арасына фахишлек таратып яталар.* Т.Гыйззәт

**ФАЦЕ́ЛИЯ** *и. лат. бот.* Кыярчалар семьялыгыннан кылсыман төкләр белән капланган туры сабаклы, зәңгәр яки алсу зәңгәр бөтеркә чәчәкле, нектарга бай баллы үсемлек. *Фацелия чәчергә җир калмады, юкә чәчәк атканчы, кортларга шикәр комы бирегез.* Г.Бәширов. *Бушап калган түтәлләргә горчица, фацелия, арыш ише сидератлар чәчеп куярга мөмкин.* Сөембикә

**ФА́Ш БУЛУ** *ф.* 1) Ачылу, беленү, дөньяга чыгу, билгеле булу. *--- мәктүп --- башка берәүнең кулына төшәчәк тә, бөтен дөньядан яшереп килгән мөкатдәс дуслык дөньяга фаш булачак...* Г.Ибраһимов. *Чын идеме ул, әкият идеме, тик ул хәбәр минем аркылы шул ук көнне бөтен малайларга фаш булды.* М.Әмир

2) Тотылу, яман ягы белән ачылу. *Берничәсе, үзенең яшерен эшләгән пычраклыгының матбугатка фаш булу ихтималыннан куркып, миңа еракган кул кушырып сәлам бирә торган булдылар.* Г.Ибраһимов. *Мидхәт, гаеп эш кылганда фаш булган адәм сыман, җайсызланып калды.* Д.Гайнетдинова

**ФАШИЗМ** *и. ит.* Террористик диктатурага нигезләнгән, үтә агрессив, шовинистик расачыл рухтагы реакцион сәяси агым. *Язмыш сукмаклары безне фашизмнан арынган Европага – ирекле Европага алып бара.* А.Шамов. *Килгән алар ерак Испаниядән азатлыкны саклап калырга һәм Пиреней ярыматавында фашизмга кабер казырга.* Ә.Исхак

**ФАШИ́НА** *и. нем. махс.* Казылган чокырның ишелмәсен өчен туфрагын ныгытуда кулланыла торган чыбык бәйләме, камыш көлтәсе

**ФАШИСТ** *и. рус* Фашизм тарафдары. *Ә фашист дигәннәре бүредән мең*

*тапкыр явызрак.* Г.Бәширов. *Бер генә минутка туктап торган фашист пулемёты яңадан котырынып ата башлады.* Г.Әпсәләмов

**ФАШИ́СТИК** *с.* Фашизм идеяләренә нигезләнгән, фашизм системасы белән бәйле. *Элек Франконың фашистик армиясендә фельдфебель булып хезмәт иткән.* А.Әхмәт

**ФАШИСТЛАНУ** *ф.* 1) Фашистка әйләнү, фашизм идеяләрен кабул итү. *Егерменче гасырда кешелек кавеменең өлешчә шактый зур тизлек белән түбәнлеккә төшә баруы, утызынчы елларда герман рухының фашистлануы, җитмешенче елларда Чили феномены --- белән бәйләнмәгәнме?* Д.Вәлиев

2) *күч.* Ерткычлык эшләү, ерткычларча җәзалау, шуннан ләззәт табу

**Фашистланып йөрү** Төрле фашистлык гамәлләре кылу. *Кайбер кадрларда Русия солдаты булып киенгән грузиннарның фашистланып йөрүе күрсәтелә, диләр.* Татарстан яшьләре

**ФАШИСТЛА́РЧА** *рәв.* Фашистларга хас булганча, нәкъ фашистлар сыман итеп. *Мондый кешеләрне халык дошманы итү – илнең коточкыч фаҗигасы ул. Бу бит – фашистларча кылануның гафу ителмәслек канлы бер өлгесе, үз иленә генә түгел, бөтендөнья юксылларына, гомумкешелеккә, үз партиянә хыянәт итү.* С.Поварисов

**ФАШИСТЛАШТЫРУ** *ф.* Фашизм идеяләрен тарату, фашистик тәртипләр урнаштыру. *Фашистлаштыру сәясәте*

**Фашистлаштыра бару** Фашистик тәртипләрне көннән-көн күбрәк урнаштыру

**Фашистлаштырып бетерү** Фашистик тәртипләрне тулысынча урнаштыру

**ФАШИСТЛАШУ** *ф.* Фашистка әйләнү, фашизм идеяләрен кабул итү

**Фашистлаша бару** Фашизмга хас сыйфатларны көннән-көн күбрәк куллану, фашистик идеяләргә нигезләнә бару

**Фашистлашып бетү** Тәмам фашистка әйләнү, фашистик идеяләрне тулысынча кабул итү

**ФАШИСТЛЫК** *с.* Фашистларга хас сыйфатлары булу, фашист булу. *Ә инде үзен тәрбияләп үстергән язучыларны гаепләп язу үзе фашистлык түгелмени?* С.Поварисов. *Украин карагруһчылары фашистлык чынызулары алсын өчен, Польша мәйданында махсус полигон төзелү дә мәгълүм.* Мәдәни җомга

**ФАШИ́СТЧА** *рәв. к.* **фашистларча**. *Һәр сүз фашистча: сүгенү дә мактану.* М.Җәлил

**ФА́Ш ИТҮ** *ф.* 1) Билгесезлекне, әлегә хәтле сер булып саналган нинди дә булса эшне, хәлне башкаларга белдерү. *Боларны сөйләгәч, Гөлбикә, йомшак дустанә бер үпкә белән, Сәхипнең аның хакында бер хикәя язуы, театрда да укырга теләве хакында халыктан ишеткәнен сөйләде, исемемне дөньяга фаш итә язгансың, дип, үпкәләвен аңлатты.* Г.Ибраһимов. *Таһир белән Зөһрә хәлләре фаш ителгән халык телендә.* Ф.Бурнаш

2) Берәрсенең начарлыгын, усал ниятләрен, планнарын тоту һәм ачып салу. --- *суд залында да синең кабахәтлегеңне фаш итәргә әзерләнүемне белдереп язам.* Г.Минский. *Аның башак урларга килгән каракларны күрәсе, күреп фаш итәсе килгән иде.* Г.Гобәй

**ФА́Ш ИТҮЧЕ** *и.* Кимчелекләр белән көрәшүче, аларны тәнкыйть итүче, белдерүче, дөньяга чыгаручы; *русчасы:* **обличитель**. *Ул, галим образын тудырганда, аның фаш итүче, көрәшче сыйфатларын калкурак итеп ачарга омтыла.* Фән һәм тел

**ФА́Ш КЫЛУ** *ф. к.* **фаш итү**. *Торабара, җае чыккан саен [Сәмигулла] кәпәчен салып, елтыр түбәсен дөньяга фаш кылыр булды.* М.Кәрим

**ФАШЛАНУ** *ф. сир. к.* **фаш булу**. *Аңа явызлык иткән агалары, хыянәтләре ачылып фашлангач, ил каршында да, тарихта да кара йөз – бәднам булып калалар.* З.Бәшири. --- *бер ай да үтмәгән, һәр якка ханның хәле фашланган.* Г.Тукай

**Фашланып бетү** Тәмам ачыклану, тулысынча фашлану

**ФАШЛА́У** *ф. сир. к.* **фаш итү**. *Бабич үзен үткен телле, күзәтүчән, бәяне төгәл бирүчән сүз остасы итеп таныта, Салтыков-Щедрин әкиятләрендә кулланган үтергеч, саркастик фашлау чалымнары күренгәндәй була.* Т.Галиуллин. *Китаплар да кешеләр кебек бит: Юкбар әдәмгә серне ачмыйлар. Баш имичә җәллад балтасына, Тираннарның йөзен фашлыйлар.* Ә.Синугыл-Куганаклы

**Фашлый төшү** Тагы да ныграк, ачыграк итеп фашлау. *Вәлетдин, тыңкышлыгын фашлый төшеп, танау эченнән җырлап җибәрде.* М.Кәрим

**ФАЭТОН** *и. гр.* 1) Борынгы грек мифологиясендә Кояш илаһы Гелиоснең утлы экипажы (аның улы атасыннан шул экипажны сорап ала да бөтен дөньяга янгын чыгара яза, шуның өчен Зевс аңа яшен ата). *Күкләрдән илаһның иңдергән яшенле фаэтоны түгел лә.* З.Мансуров

2) Дүрт тәгәрмәчле, өсте ачылмалы җиңел экипаж. *Чалма-чапаннарын киеп, әзерләнеп торган ишан хәзрәтләре, яшел таягын алып, ашыкмыйча гына фаэтонга чыгып утыра.* Ә.Еники. --- *көмеш тәңкәләр белән бизәлгән, тарантас-мазар гына да түгел, фаэтон җигелгән, ат башында куе кара сакаллы кучер утыра.* К.Миңлебаев

3) Ян-яклары алына торган кузовлы, өсте ачылмалы җиңел машина. *Сезнең фаэтон сарайда калды, командир иптәш, Мостафин аның ачкычын кесәсенә салып киткән.* Ш.Усманов. *Фаэтонда җилдерү*

**ФАЭТОННАР** *и. гр. күпл. зоол.* Яхшы оча, ләкин начар йөзә һәм чума, авыр йөри торган ишкәгаяклы океан кошлары семьялыгы атамасы

**ФАЯНС** *и. ит.* **1.** 1) Югары сыйфатлы савыт-саба ясау өчен, үзенчәлекле составка ия булган балчыкка гипс һ.б. катнашмалар кушып әзерләнгән ак яки төсле масса. *Бу [пластмасса] эшләнмәләр җиңел һәм коррозиягә чыдам, фаянс һәм чуенга караганда арзанрак.* Төзү материаллары

2) Шул массадан ясалган һәртөрле әйберләр. *Фарфор һәм фаянс залларында гарәп сүзләре, гарәп җөмләләре белән бизәлгән Иран савыт-сабалары музейчыларны үзләренә тарталар.* Г.Гобәй

**2.** *с. мәгъ.* Шул массадан яндырып, ялтыратып ясалган. *Чи йомырканы сытып, сарысын фарфор яки фаянс савытка салалар да, тоз сибеп, махсус туглагыч яки калак белән бик яхшылап туглыйлар.* Йорт эшләре

**ФӘГАЛИЯТ** *и. гар.* 1) Эшчәнлек, эшлеклелек. *Менә шул фәгалият, шул эш арасында, җитмәсә, Муса әфәндeнең үзе ята торган караватында мин авырып, йөткереп, гадәт буенча папирос тартып ятам.* Г.Тукай. *Ризаэддин хәзрәт «Шура»дагы мәкаләләре вә кыйммәтле «Асар»ы илә элекке вә соңгы милли тарихыбызда әһәмиятле урын тоткан аерым шәхесләр вә аларның фәгалиятләре илә таныштырды.* Г.Шәрәф

2) Активлык. *Авазларны чыгаруда фәгалият шул ике әгъзада [ирен һәм телдә] булып, теш һәм каты аңкауның катнашуы, үзләре тик торган хәлдә,*

*тегеләргә ярдәм итүдән генә гыйбарәттер.* Җ.Вәлиди

◊ **Фәгалияткә чыгару** Эшкә, тормышка ашыру, гамәлгә кую. *Боларны фәгалияткә чыгарыр өчен – милләт тарафыннан ышаныч казанган кешеләрнең идарәсенә бирер өчен – милли бер фонд әзерләү кирәктер.* Г.Исхакый

**ФӘГГАЛЬ** *с. гар. иск.* **1.** Эшчән, күп эшләүче, һаман хәрәкәт итүчән, актив. *Рухымны авыр, тын, ләкин бик фәггаль бер изтыйраб ала.* Г.Ибраһимов

**2.** *и. мәгъ.* Эш. *Халык эшләренә калмаган һич теләк, сурәтләре – алиһи, фәггальләре – шәһвәти.* Б.Вәисев

**ФӘГЪФУР** *и. фар. иск. к.* **фарфор**. *Фәгъфур касәләргә тутырып шәраблар китерделәр.* К.Насыйри

**ФӘЕЗ** *и. гар. иск.* 1) Рәхимлелек, шәфкатьлелек, бәрәкәт. *Бөкре түгел, төзәлергә кабер көтмим, тәңрем фәйзы минем күңлемә эз салыр.* Г.Тукай. *Фәйзы хак һәр мөмкинә гам – шарт имәс Багдад-Хәләб...* М.Акмулла

2) Белем. *Бездән дә фәез бабы бикләнгән юк.* М.Акмулла

**ФӘЗА** *и. гар.* Күктәге (һавадагы) ачык урын, бушлык, ачыклык, пространство. *Мин күрәмен киң фәзаның ай белән йолдызларын.* М.Гафури. *Кеше һәм табигать бәйләнешләре вакытта һәм фәзада бер-берсен алыштырып тора.* Фәнни Татарстан

**ФӘЗАХӘТ** *и. гар. иск.* Оят, хурлык, рисвайлык. *Бу фәзахәт халыкка улмыш табигать – кайда нәсыйхәт алмак боларга.* Б.Вәлиев

**ФӘЙЛӘСУФ** *и. гар. иск. к.* **философ**. --- *бөтен голәма вә фәйләсуфлардан артык иканлекләрен дәгъва кылулары бертөсле булганга, болар берберенә ифрат дәрәҗәдә охшашлылар.* Г.Тукай

**ФӘЙТУН** *и. сөйл. к.* **фаэтон** (*2 мәгъ.*). *Даһианә ничә мең наз илә боргаланып, фәйтунга утырып, уен бакчасына китте.* Ф.Халиди

**ФӘ́КАТЬ** *терк. гар.* **1.** Бары, тик, бары тик. *Курыкмагыз, кошлар, күреп сез яныгызда мин барын; Мин тимәм сезгә, фәкать сайравыгызны тыңлармын.* Г.Тукай. *Фәкать краннардан берәнсәрән тамган тамчыларның тавышлары гына бу тынлыкка үзе бертөрле эчпошыргыч хәят бирә иде.* Ф.Әмирхан

**2.** *кис. мәгъ.* Бары, бары тик, тик, кына. *Әмма хәзерге чорда кешенең көче фәкать акчада гына икәнне белеп алган Хафиз.* Ә.Фәйзи

**ФӘКЫ́ЙРАНӘ** *рәв. гар.* **1.** 1) Ярлыларча, ярлылар кебек, ярлылар рәвешендә. *Дәхи ят кеше янына --- кергәндә җиһазым булмаса, кием-салым фәкыйранә булса, халык арасында хурфәкыйрь күренермен, оялырмын, дип куркып егълыймын.* К.Насыйри

2) Түбәнчелек белән, баш иеп. *Әле кичәге көндә генә «Совет әдәбияты» журналының авыр һәм куркыныч ишекләре янында хәер эстәп йөрүче ятим бала сыйфатлы фәкыйранә оялуда басып торды.* Ф.Яхин

**2.** *с. мәгъ.* Түбәнчелекле, түбәнчелек белән сораган. *Олуг хан, вәгъдә бирдең син: фәкыйранә теләгемне тәмам бирмәкче булдың бит бөтенләй үз теләгеңдәй.* Г.Тукай

**ФӘКЫЙРӘ** *с. гар.* Фәкыйрь хатынкыз. --- *анам мине авылыбыздагы Шәрифә исемле бер фәкыйрә карчыкка вакытлыча асрарга биреп калдыра.* Г.Тукай

**ФӘКЫЙРЬ** *с. гар.* **1.** 1) Ярлы, мохтаҗ. *Фәкыйрь кеше! Кемнәр сиңа иман таккан? Тәзкирәңә мөслим диеп игълан таккан?* Г.Тукай

2) Сәләмә, иске. --- *безнең артта авыл читендәге иң фәкыйрь йорт --- торып калды.* Ә.Еники. *Ләкин аны артык гади, артык фәкыйрь киемнәре харап итә.* Т.Әйди

**2.** *и. мәгъ.* 1) Җитешсез тормышта яшәгән, мохтаҗ, ярлы кеше. *Фәкыйрьнең дусты – кояш.* Әйтем. *Мескен фәкыйрь, иркен сулыш та алмыйсың, аһваһыңнан һичбер вакыт бушанмыйсың.* Г.Тукай

2) **фәкыйрегез** Сөйләүченең үзен телгә алуы; хадимегез. *Әниебез өч бала били: Зәйнәп исемлесе бик бәләкәй чакта ук дөнья куя; апам Фәүзия исән-сау; без фәкыйрегез, шыгырдап алгаласа да, яши бирә.* К.Миңлебаев

**3.** *рәв. мәгъ.* Ярлы, мохтаҗ хәлдә. *Фәкыйрь калдым хәзер: тормыш үзенең биргәнен алды; күңел буш: анда калды тик авыр хәсрәт, ачы кайгы.* Г.Тукай. *Әйе, без фәкыйрь яшәдек.* А.Расих

**ФӘКЫЙРЬЛӘНҮ** *ф.* Фәкыйрь хәлгә төшү. *Күрәмсез, нинди беткән һәм арыкланган, фәкыйрьләнгән.* Г.Тукай. *Көнбатышта фәннең, техниканың, мәдәниятнең үсүе, анынча Шәрыкның бик нык таралуына, фәкыйрьләнүенә китерде.* М.Мәһдиев

**Фәкыйрьләнә бару** Көннән-көн ныграк фәкыйрьләнү. *Мәрхүм: «Көзге төн, мин йоклый алмыйм, Куркусыннан ил елый», – дип язган иде. Чыннан да, улым, халык елдан-ел бөлгенлеккә төшеп, елдан-ел фәкыйрьләнә бара.* Т.Гыйззәт. *Иң бай илдә яшәп, иләте дә фәкыйрьләнә бара нигәдер.* Г.Морат

**Фәкыйрьләнә башлау** Фәкыйрьлекнең беренче билгеләре күренү

**Фәкыйрьләнә төшү** Тагын да фәкыйрьләнү; бераз фәкыйрьләнү

**Фәкыйрьләнеп бетү** Тәмам, бөтенләй фәкыйрь хәлгә төшү, бик нык фәкыйрьләнү. *Адәм баласы түгел, эт тә йөри алмас пычрак төн. Бер тракторчы фәкыйрьләнеп беткән калтырча «Белорус»енда көчкә начилы өенә кайтып бара.* Р.Гаффар

**Фәкыйрьләнеп калу**Ниндидер сәбәпләрдән, шулар тәэсире белән фәкыйрьләнү. *Бәгъзы кешеләр --- фәкыйрьләнеп калалар.* Г.Тукай. *Син алай юмартланма, барыбер бәяләмәсләр, үзең генә фәкыйрьләнеп калырсың.* Х.Камалов

**Фәкыйрьләнеп китү** Кинәт фәкыйрьләнү; бераз фәкыйрьләнү. *Тел байлыгым фәкыйрьләнеп киткән кебек тоелса, Фатих Хөсни белән Мөхәммәт Мәһдиевкә тотынам.* Казан утлары

**ФӘКЫЙРЬЛӘ́РЧӘ** *рәв.* Фәкыйрьләргә хас булганча. *Янында инде өлкән яшькә җиткән, фәкыйрьләрчә киенгән, яулык бөркәнгән әнисе дә бар.* Шәһри Казан

**ФӘКЫЙРЬЛЕК** *и.* Фәкыйрь булу. *Тол хатын һәм ике үсеп килгән малай чибәр генә йортта калсалар да, шактый фәкыйрьлектә яшәделәр.* Ә.Еники. *Яшь ягыннан аермабыз зур түгел. Аерма тик шунда гына: Шәфикъ үсә муллыкта, «индук» малае – фәкыйрьлектә.* К.Миңлебаев

**ФӘКЫЙРЬ-ФӨКАРА** *җый. и. гар.* Фәкыйрьләр, мохтаҗлар, ярлы-ябага. *Аннан соң, Коръән укып тәмам булгач, хәленә күрә акча өләшәләр: шунда кабер тирәсендәге кешеләргә, фәкыйрьфөкарага.* К.Насыйри. *Увельканың агымга түбән өлешендә ике ярда да вак алачыклар тезелеп киткән, анда күпчелеге татарлардан торган фәкыйрьфөкара яши.* А.Расих

**ФӘКЫЙҺ** *и. гар.* Фикъһ белгече, ислам шәригатен өйрәнүче илаһиятчы. *Хокукчы вә фәкыйһ кешесе буларак, әйт әле, әмир Хаҗи урманнарында качкыннар күбәеп киткән икән, атакайлары кем, белмәдеңме?* М.Хәбибуллин. *Алмас, аңарга [Багдад хәлифәсенә] илчеләр җибәреп, үз илендә ислам тәртипләрен урнаштыруда ярдәм итү һәм*

*болгарларга мөселман динен өйрәтү өчен, үзенә фәкыйһ – шәригать хокукларын яхшы белүче кеше җибәрүне үтенгән.* Р.Фәхретдинов

**ФӘКЫР** *и. гар. иск.* Ярлылык, фәкыйрьлек. *Сәнең фәкырең – дорыр фәхрең, онытма, моның дик юк фаразлә кайгы йотма.* Г.Тукай

**ФӘЛАКӘТ** *и. гар.* Бәла, бәхетсезлек, һәлакәт, афәт. *Казанның җимерелүе алар өчен фәлакәткә тиң.* Ф.Латыйфи. *Фәлакәтнең әллә нинди куркынычлы дулкыннары арасында йөзгәндә, өметсезләнеп йөрәк сызлаганда, --- ул шул моңлы тавышны ишеткән төсле була.* С.Җәлал

**ФӘЛӘК** *и. гар.* 1) Йолдызлары белән бергә күк гөмбәзе (астрологиядә кеше язмышын билгеләү белән бәйле). *Фәләк – күкне борып, йолдыз йөреткән.* Котб. --- *аңар күрә үземне бик түбән саныйм, аның урны фәләкләрдә, гарештә, дим.* Г.Тукай

2) *күч.* Бәхет, язмыш, тәкъдир. *Алга сәвекъ ит сахибеңне, бул чыдаулы таш кеби, и фәләкнең төрле-төрле зольменә күнгән күңел!* Г.Тукай. *Көтмәгәндә кайгы салды безгә кадәр бу каһәр фәләк.* М.Гафури

**ФӘЛӘН** *а.* 1) *Шул, теге, шундый* алмашлыклары урынына аныксызлык, билгесезлек төсмере белән әйтелә. *Докладмы анда, политинформацияме, фәләнме – аңа гына бир.* Г.Бәширов. *Ә бит, мамык яхшырак үссен дип, ул җирләрне фәлән дистә еллар дәвамында пестицид, нитрат, нитритлар белән дыңгычладылар.* Татарстан яшьләре

2) Парлы сүзнең икенче компоненты булып килеп, җыелмалылык төсмере белән «шуның ише, шуңа охшаш әйберләр» дигән мәгънәне белдерә; мазар, кара. *Мин тәмам гиздем җиһанны, кайда, кайда йөрмәдем, тик шул алтыннан бәла, шайтан-фәлән һич күрмәдем.* Г.Тукай

**ФӘЛӘН-ТӨГӘН** *а. сөйл.* 1) Әһәмияте булмаган вак-төяк эшләр, күренешләр, нәрсәләр; теге-бу, ул-бу, юкбар, шуның ише. *Дөрес, кышын дым тарта, өе салкын була, фәлән-төгән дип, кайберәүләр кул да селтәде аңа.* Р.Вәлиев

2) Ачулану, тиргәү сүзләрен алмаштырып кулланыла. *Әшне бик төптән кузгатмыйк инде, син – фәлән, син – төгән, дип кычкырмыйк, югарыда әйткәнчә, хәйран булып кына калыйк инде.* Г.Тукай

**ФӘЛӘН-ФӘСМӘТӘН** *и. к.* **фәлән-төгән**. *Әйбер кыйммәт, фәлән-фәсмәтән, дип сөйләнә башладылар.* А.Расих. *Чәчрәп яклыйм тагын, куып җибәргән, фәлән-фәсмәтән, дим.* Н.Гыйматдинова

**ФӘЛСӘФӘ** *и. гар.* 1) Философия. *Менә шушы телдән аралашу барышының теге яки бу өлешен өйрәнү ягыннан фәлсәфә, логика, лингвистика, психология фәннәре бер-берсе белән тыгыз мөнәсәбәттә торалар.* Татар грамматикасы

2) *күч.* Фикерләү, уйлау, нәтиҗәләр ясауга нигезләнгән карашлар җыелмасы. *Бу хәзинәгә халык үзенең ничә мең еллар буенча тупланган тормыш тәҗрибәсен, яшәеш турындагы фәлсәфәсен, үзенең иҗатын, гореф-гадәтен --- ышанып тапшырган.* Г.Бәширов. *Халкыбызның җырларын тикшереп карасаң, искитәрлек фәлсәфә һәм табигать белән бердәмлек.* М.Мәһдиев

◊ **Фәлсәфә кору** 1) Төрлечә уйлап, нәтиҗәләр ясап фикер йөртү. *Мин үземчә шулай мәсьәләнең һәр ягын исәпкә алып, төрлечә фәлсәфә корып, бу фәлсәфәмнең әле бу, әле теге ягын тикшереп ятам.* А.Расих. --- *фәлсәфә корырга, фикер үткерлеген чарларга омтыла торган төпле кеше икәнлеге беленде.* М.Маликова; 2) *к.* **фәлсәфә сату**. *Дасаев хәтта кемнеңдер Морис Бежар балеты турында фәлсәфә коруын да ишетеп алды.* Р.Мирхәйдәров. **Фәлсәфә сату** Акыл сату, буш сүз сөйләү. *Саталар фәлсәфә анлар, оралар дәм дә хикмәттән, аяк астында базны күрмиләр шул хәлдә гафләттән.* Г.Тукай

**ФӘЛСӘФӘ́ ТАШЫ** *и. кит.* 1) Алхимикларның уйлавына күрә, гади металлны алтынга әйләндерергә сәләтле хыялый матдә, тылсымлы таш

2) *күч.* Даос фәлсәфәсендә рухи дөньяда гына хәзинә табарга омтылу, тормышның вак-төяк мәшәкатьләреннән аерылып, бар булганына риза булып, фәлсәфи камиллеккә ирешергә омтылудан гыйбарәт яшәеш принциплары. *Даос фәлсәфәсендә үлемсезлек турында Дань тәгълиматы бар, ул фәлсәфә ташы дип атала.* Р.Батулла. --- *шомарып беткән таш кисәкләре генә түгел, ә бәлки чынбарлыкны аңларга омтылу символы, фәлсәфә ташы, кешенең үзенең зурлыгын аңларга, үз урынын табарга омтылу чарасы да.* Р.Фәйзуллин

**ФӘЛСӘФӘЧЕ** *и.* Философ. *Николай Бердяев хезмәтләрен укып маташтым. Атаклы урыс фәлсәфәчесе икән ул.* Т.Әйди. *Материалист фәлсәфәчеләр, матдә – мәңгелек, ул төрле үзгәрешләр генә кичерә һәм арта да, кими дә алмый, диләр.* Казан утлары

**ФӘЛСӘФИ** *с. гар.* Философик. *Фәлсәфи планда ул – эчтәлек һәм форманың каршылыклар берлеге.* Татар грамматикасы. *Тирән эчтәлекле, фәлсәфи әсәрләргә мөрәҗәгать итүе белән тәнкыйтьчеләрнең дә, тамашачыларның да мәхәббәтен казанды.* Казан утлары

**ФӘН** *и. гар.* 1) Өйрәнү, танып белү, тәҗрибә юлы белән табигать, җәмгыять, фикерләү үсеше законнарын тикшерү, системага салу, яңа белем синтезлауга һ.б. юнәлгән эшчәнлек төре; аның аерым тармаклары. *Саба үзәк шифаханәсендә педиатр булып башлый да фәнгә кереп китә ул. Кандидатлык диссертациясен уңышлы яклый.* Т.Нәҗмиев

2) Мәктәп, уку йорты программасына нигезләнеп укытыла торган аерым гыйлем тармагына караган предмет. *Син бик тырыш күренәсең, җиденчедә укыганда сигезенчедә үтелә торган фәннәрдән дә кайберсе белән шөгыльләнерсең, шулай итеп, әгәр булдыра алсаң, җәйгә кадәр, бәлки, сигезенче классны да тәмамлап чыгарсың.* А.Расих

◊ **Фән әһеле** *к.* **фән иясе**. *Кайчандыр фән әһелләре халык арасында иң яхшы тәэмин ителгән катлаудан санала иде.* Ә.Еники. **Фән иясе** Галим, укымышлы, фән белән шөгыльләнүче кеше; фән әһеле. **Фән кандидаты (докторы)** Нинди дә булса фән тармагы буенча кандидатлык (докторлык) диссертацияләре яклап, шундый гыйльми дәрәҗә алган кеше. *Картның ике улы, ике кызы бар, һәммәсе дә мөхтәрәм кешеләр, икесе – фәннәр кандидаты...* Р.Мостафин

**ФӘНА** *и. гар. иск.* **1.** 1) Фанилык. *Гакылыма шул килде ки, бу фәна милкемнән китмәс борын сиңа берничә нәсыйхәт бирсәм кирәк ки, дәүләт вә сәгадәт юлына сиңа җитәкче булсын.* К.Насыйри

2) Югалу, юк булу, юкка чыгу, бетү, һәлакәт. *Гыйшыклык бер кадәхтер ки, эчендә фәна уты янар: ул һәлак булыр.* К.Насыйри

**2.** *с. мәгъ.* 1) Фани, бетә торган. *Зур җаным сөйми җиһанны, чөнки бар дөнья фәна.* Г.Тукай

2) Начар. *Фәна вә яман гадәтләргә өйрәнүдән яшь вакытта бик*

*сакланырга тиеш икән, начарлыгын белсәң дә, гадәтләнгән нәрсәне ташлавы бик читендер.* Ф.Кәрими. *Урлыйбыз, ди, җан фида, ди барсы да, юкса шунсыз эш фәна, тормыш җөда.* Ш.Бабич

**ФӘННИ** *с. гар.* Фәнгә нигезләнгән, фән белән бәйле. *Үзенең фәнни эзләнүләрен Г.Исхакый әсәрләрен иленә кайтару һәм дөньяга чыгару кебек игелекле эшкә багышлаган галимә.* Сөембикә

**ФӘННИ-ГАМӘЛИ** *с. гар.* Билгеле бер өлкәдә һәм фәнни, һәм гамәли эшчәнлек белән бәйле булган. *Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте 17–18 февральдә Казанда мәшһүр татар дин әһеле Галимҗан Барудиның тууына 160 ел тулу уңаеннан «Россия мөселманнарының рухи мирасын өйрәнүнең актуаль проблемалары: тарих һәм бүгенге заман» дип аталган халыкара фәнни-гамәли конференция уздыра.* Н.Сабиров

**ФӘННИЛЕК** *и.* Фәнни нигезләнгәнлек, фәнгә нигезләнгән булу. *Мәгълүм булганча, XIX йөзнең икенче яртысында, Шиһабетдин Мәрҗани, Хөсәен Фәезханов, Каюм Насыйри һ.б. тырышлыгы нәтиҗәсендә, татар тарихи белеме фәннилек нигезендә оеша.* М.Госманов. *Әмма шуны бер төзек, фәннилеккә дәгъва иткән хәлгә китерү шактый четерекле эш булып чыкты.* Ф.Галимуллин

**ФӘННИ-ПОПУЛЯР** *с. гар.-лат.* Һәм фәнни, һәм популяр; фәнгә бәйләнешле фикерләрне гади, һәркемгә аңлаешлы итеп шәрехләгән. *Б.Солтанбековның «Гудериан Казанда» дигән фәнни-популяр очеркыннан күренгәнчә, Гудериан Казан мәктәбенә немец офицерлары-курсантларын әзерләүне тикшерү өчен генә килгәндер кебек.* Д.Шәрәфетдинов. *«Сөембикә» китабы иҗат ителгән чорда әдәби телебезнең фәннипопуляр стиле әле тәмам оешып, утырып җитмәгән иде.* М.Госманов

**ФӘННИ-ТЕОРЕ́ТИК** *с. гар.-гр.* Фәнни теорияләргә нигезләнгән, фән таләпләренә җавап бирә торган. *Муса Җәлилнең тууына 80 ел тулуга багышланган фәнни-теоретик конференция бара.* М.Мәһдиев

**ФӘННИ-ТЕ́ХНИК** *с. гар.-гр.* Техника-технология һәм фән өлкәсенә караган. *Мәктәп укучылары өчен Россиякүләм фәнни-техник иҗат бәйгесе башланды.* Әтнә таңы

**ФӘ́НЧӘ** *рәв.* Фәнни телдә, фәнни ачышларга, законнарга нигезләнеп. *Ләкин ул вакытта халык сөйләгәнчә генә язу килешмәгән, күрәсең, алай фәнчә булмаган.* Г.Бәширов. *Җир грушасы, фәнчә, топинамбур дигән, шалкан, чөгендер, кишер кебек туфракта, аста үсә торган ризык турында ишеткәнең бармы?* Т.Галиуллин

**ФӘРАВАН** *с. фар. иск.* Күп, мул. *Анда нәфис һава фәравандыр.* К.Насыйри

**ФӘРД** *и. гар. иск.* 1) Бер, бер бөртек; ялгыз, аерым

2) Аерым зат, шәхес, берәү, индивид. *Милли вөҗдан – --- милләтнең һәр фәрденең күтәрелү һәм төшүенә үз күтәрелү вә төшүенә мөсави итеп хис итүдән вә шулай хис итүгә тырышудан гыйбарәттер.* Г.Шәрәф

3) *лингв.* Берәмлек. *Эчтәлекләре ягыннан мәкаль вә әйтемнәргә яки канатлы сүзләргә тартым булган фәрдләргә афористик яңгыраш типик күренеш санала.* Ә.Синугыл-Куганаклы

**ФӘРЕХ** *и. гар. иск.* Шатлык, сөенеч, күңел күтәренкелеге

**ФӘРЕХБӘХЕШ** *с. гар.-фар. иск.* Шатлыклы, шатландыра торган. --- *киемең пакь, хәтерең хуш булсын, таки барган җиреңдә [син] фәрехбәхеш булгайсың.* К.Насыйри

**ФӘРЕХЛЕК** *и. иск. к.* **фәрех**. *Минем күңелем фәрехлек илә тулмыш иде.* М.Акъегетзадә

**ФӘРЕШТӘ** *и. фар.* 1) *дини* Аллаһ белән кеше арасында арадашлык иткән һәм нурдан яратылган рухи барлык, зат. *Әрекмән – кәбестә, адәм фәрештә булмас.* Әйтем. *Кабер очында, ниндидер бер фәрештәнең Әсмабикә әби белән сөйләшергә килүен ишетер өчен, Яхъя карт ялгыз үзе генә утырып калды.* Ә.Еники

2) *күч.* Үз-үзен тотышы, кылган гамәлләре белән фәрештәне (*1 мәгъ.*) хәтерләтерлек игелекле зат; гөнаһсыз кеше. *Газига да, эш урынында гел халат белән күренгәнгәме, Фәрештә дигән кушамат тактылар.* М.Хәсәнов. *Һәм [Мәрьям апай] япь-яшь килеш имансыз көчләргә каршы чыккан, бөтен авыл халкын яклаган, ә бәлки кемнәрнедер һәлакәттән дә саклап калган фәрештә.* Р.Фәизов

3) *күч.* Рухи матурлык, гүзәллек, илаһилыкны гәүдәләндергән зат. *Җир фәрештәсенә тиң затка дәгъва кылырлык хокук бирәләр.* Ф.Латыйфи. *Моңлан әйдә, моңнар фәрештәсе, Искә төшер иске хәлләрне.* Т.Ченәкәй

4) **фәрештәм, фәрештәкәй** Иркәләп эндәшү сүзе. *Нигә бүген элеккечә елмаймыйсың син, күктән иңгән фәрештәм?* З.Мәхмүди

**ФӘРЕШТӘ УТЫ** *и. бот.* Чатырчәчәклеләр семьялыгыннан куыш сабаклы, ак яки саргылт яшел чәчәкле, каурыйсыман яфраклы икееллык яки күпьеллык эре үлән үсемлек; курай үләне, курай, шома көпшә, шүре үләне, шүрелек; *русчасы:* **дягиль**. *Дару өчен фәрештә уты үләненең тамырын яз башында һәм үләнен май аенда җыярга кирәк.* К.Насыйри

**ФӘРЕШТӘ́ ЧӘЧӘГЕ** *и. бот.* Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан ачык зәңгәр чәчәкле, каты сабаклы, киптерелгән тамыры кофе суррогаты алу һәм чын кофега кушу өчен кулланыла торган күпьеллык үсемлек; һиндыба, буынчәчәк, бишбармак чәчәк, буынлы үлән, күнаяк. *Әйтик, женьшеньны үзебезнең әрекмән, цикорий (буынлы үлән, фәрештә чәчәге) һәм тузганак тамыры белән алыштырырга мөмкин* Шәһри Казан

**ФӘРЗӘНД** *и. фар. иск.* Бала. *Гаҗәп, хәйран булыр фәрзәнде адәм, якын бармыйк, аның асты җәһәннәм.* Г.Тукай

**ФӘРМАН** *и. фар.* Ислам дәүләтләрендә хөкемдарның туграсы салынган һәм үтәлүе берсүзсез тиеш булган боерык, әмер, указ. *Кайчан, кем сайлады, Тәңре, мине, бу – хак пигамбәр, дип, Мине фазлына лаек күрде, фәрманым төгәлләр, дип.* Г.Тукай. *Анда бер айга якын торганнан соң, Байкал артына «кышкы квартираларга» кайтырга фәрман булды.* Г.Ахунов

**ФӘРМА́Н КЫЛУ** *ф.* Боеру, әмер бирү. *Шул мизгел Аллаһы Тәгалә Җәбраилгә фәрман кылды: – Минем ул бәндәмне тот, ул, минем газабымнан куркып, үзен һәлак кылырга тора, – диде.* К.Насыйри

**ФӘРМАНЧЫ** *и.* Фәрман бирүче. *Бер язмада баш фәрманчының үтерелмәвенә үкенеч белдерелә.* К.Латыйп

**ФӘРРАШ** *и. гар.* Мәчет-мәдрәсәне карап торучы, каравылчы. *Әстерханның зур мәчетләренең берсендә фәрраш булып торганлыгын --- сөйләп алды.* Г.Ибраһимов. *Бу дөмбәсләшү, мәктәпнең йозагын фәрраш килеп ачканчы, туңмас өчен һәм вакыт уздыру теләге белән ясала торган көндәлек маҗара икән.* Ә.Фәйзи

**ФӘРСӘХ** *и. гар.* 6–7 чакрым чамасындагы ераклык үлчәү берәмлеге.

*Утынлык урман шәһәрдән бер фәрсәх читтә иде.* Г.Фәезханов

**ФӘРЫК** *и. гар. иск.* 1) Аерма, башкалык; үзгәлек, башка төрле булу. *--- песиләр --- икәүләп куркалар, тик бераз бу куркуларның бер-береннән фәркы бар.* Г.Тукай. *Фәркы нәсәб вә фәркы җенес игътибарга алынмасын.* Г.Рәхмәтуллина

2) Аеру. *Шул сәбәптән дусны, дошманны дөрес фәрык итмичә, күп саташтырдык рәзил шайтанны чын инсан белән.* Г.Тукай

**ФӘРЬЯД** *и. фар. к.* **фөрьяд**. *Язмышына аһ вә фәрьяд әйләгәч ---.* Ш.Бабич

**ФӘС** *и.* 1) Мароккодагы Фас шәһәре исеменнән алынган: мөселман илләрендә киелә торган, киселгән конуссыман формалы, гадәттә кызыл төстәге, чуклы милли баш киеме. *Биниһая зур башлы гөмбәз кадәр, ни сәбәптәндер башында фәс тә бар.* Г.Тукай

2) *гади сөйл.* Патша Россиясендә җитештерелгән рус аракысының шешә башы кызыл сургуч белән томаланган булудан аны фәсле төрек кешесенә охшатып әйтү. *Бу шатлыктан «төрек малае»ның «фәс»ен сугып очырмыйча ярамый.* К.Нәҗми

**ФӘСАД** *и. гар.* 1) Бозык, бозыклык, азу. *Тәкъва, суфи байларның чиктән узды фәсады.* Г.Тукай

2) Тыелган эш, җәмгыять каршында каралаучы гамәл. *Ни кыйлмакчы буласыз, нинди фәсад чыгарырга телисез тагын.* Г.Ибраһимов

3) Фетнә

**ФӘСАНӘ** *и. фар. иск.* Миф, әфсанә, уйдырма. *Бу дәм күрендегем, бу бер фәсанә.* Дәрдемәнд

**ФӘСАХӘТ** *и. гар.* Матур теллелек, телдә үткенлек, ягымлылык, ятышлылык. *Бик горурлы ул, сиңа һич ихтыяҗы булмас; бер эше төшсә әгәр, балдан фәсахәт күрсәтә.* Г.Тукай. *Бер фәсахәт иясе вә сүзгә остаз адәмне илче итеп Һиндстан тарафына күндерделәр.* К.Насыйри

**ФӘСАХӘТЛЕ** *с.* 1) Тапкыр, җор телле; матур сөйләүчән

2) Нәфис, образлы, сәнгатьле. *Фәсахәтле стиль*

**ФӘСЫЙХ** *с. гар.* Матур, килешле, әдәби тел нормаларына туры килгән. *Былбыл кебек фәсыйх телен ачып әйтте.* К.Насыйри. *Мулла Шәрифи әфәнде үзенең озын вә фәсыйх мәкаләсен болай башлады.* Ш.Камал

**ФӘТВА** *и. гар.* Ислам хокукы белән бәйле берәр мәсьәләнең дини хокук кагыйдәләре нигезендә чишелешен аңлаткан, шәйхелислам яки мөфти хәзрәтләре тарафыннан чыгарыла ала торган карар, документ. *Иртәгә, фәтва сорау өчен, дамелла Котбетдингә барырга ният итте.* Г.Газиз. *Кубыз чиртмәк, сурәт ясамак, тәкә сөзештермәк, аю биетмәк – харамдыр, дип тискәре фәтва биргән.* К.Нәҗми

**ФӘТХӘ** *и. гар.* Гарәп язуында берәр тартыкка [а] яки [ә] авазы кушып укылганын белдерә һәм хәреф өстенә куела торган хәрәкә

**ФӘТХӘЛЕ** *с.* Фәтхә белән укылган, өстенә фәтхә хәрәкәсе куелган. *Бу чор истәлекләре текстларында әлиф, вау, йа хәрефләренең фәтхәле вариантлары күренми.* Татар әдәби теле тарихы

**ФӘҮКЫЛЬГАДӘ** *с. гар.* **1.** Гадәттән тыш, искиткеч. *Боларның тәрбиясе фәүкыльгадә бер эш көткән.* М.Гафури. *Икенче көнне үк инде бу фәүкыльгадә вакыйганы бөтен таныш-белешләре исләре китеп сөйләячәкләр.* Ә.Еники

**2.** *рәв. мәгъ.* Гадәттән тыш, гаҗәп. *Кан елый күп чакта, фәүкыльгадә тордым, дип кеше.* Г.Тукай

**ФӘХЕШ** *и. гар.* **1.** Бозыклык, бозык эш, уйнаш, зина. *Килешмидер Коръән уку, тәсбих әйтү фәхеш, вәхшәт берлән тулган ханәдә.* Г.Тукай

**2.** *с. мәгъ.* Шул сыйфатларга ия булган. *Төн эчендә, күпме акча түгеп, Күбегез ята фәхеш кызлар үбеп.* Г.Сәгыйров

**ФӘХЕШХАНӘ** *и. гар.-фар.* Фахишәләр йорты, тәтәйләр йорты, кызыл фонарь. *Озакламый ул, сынау чорын үтеп, фәхешхананең тулы хокуклы әгъзасына әвереләе.* Н.Гыйматдинова. *Союзда ел эчендә төзелгән иң әйбәт саналган биналарның барысын бергә алганда да, алар Эфес шәһәрендәге фәхешханә җимерекләренә дә тормыйлар.* Р.Мирхәйдәров

**ФӘХРИ** *с. гар. иск.* Мактаулы, хөрмәтле. *Мондый хәрәкәтләрнең һәммәсенә махсус фәхри исемнәр бирелгәнен бәян итте.* Ф.Әмирхан. *Ул «Финляндия җәмгыяте исламия»нең фәхри әгъзасы Гомәр Абдрахиның 80 яшь тулу уңае белән язылган.* И.Надиров

**ФӘҺЕМ** *и. гар.* 1) Аң, зиһен, акыл, зирәклек. *Фәһме артсун, хәтре рушан улсын.* Кол Гали. *Батарсың син, сине ул төпкә тартыр, Бу – чын сүз; тыңладыйсаң, фәһмең артыр.* Г.Тукай

2) Аңлау, төшенү дәрәҗәсе. *Әл Кадиринең кадре төшмәк әлмисактан кадир. Гаклына, фәһменә истибдатлы хиссият мөдир.* Ш.Бабич

◊ **Фәһем алу** Сабак алу, белем, тәҗрибә туплау. *Үсә төшкәч, мин язганны укырсың да фәһем алырсың.* М.Кәрим. **Фәһем җыю** Аңны бер юнәлешкә юнәлтү, акылны туплау. *Кыяметдин иптәш, минә яшь белгеч, фәһем җыеп, авылыбызга кайтты.* Г.Ахунов

**ФӘҺЕ́М ИТҮ** *ф. к.* **фәһемләү**. *Бәлагать вә фәсахәт шулдыр: хаслар ишетсәләр – разый булырлар вә гавам ишетсә – фәһем итәр ки ---.* К.Насыйри. *--- үзең белән үзең генә калган хәлдә фәһем иткәндә, Нуриәсма гаепсез иде.* Ф.Садриев

**ФӘҺЕМЛӘ́Ү** *ф.* 1) Уйлау, фикерләү, фикер йөртү. *Бу эшне Бәхтияровка гына йөкләргәме икән әллә, дип тә фәһемләгән иде, үзе тикшерүне артыграк күрде.* М.Насыйбуллин

2) Аңлау, төшенү, белү. *Кеше ни әйтә, әүвәл яхшы тыңлап, аның сөален фәһемләмәк кирәк, сөален фәһемләмәсәң дә, мәгъкуль җавап бирмәк кирәк.* К.Насыйри

**Фәһемләп кую** Кинәт фәһемләү, аңлап алу. *Шуңа да фәһемләп куйдым, бу егетнең башында бүтән планнармы әллә, дим.* Казан утлары

**Фәһемли бару** Торган саен ныграк, күбрәк фәһемләү; һәрберсен, ишеткән, әйткән берсен фәһемләү

**Фәһемли башлау** Фәһемләргә керешү. *Аннары, бездән күреп, алар да игенчелек, яшелчәчелекне күбрәк фәһемли башладылар...* Т.Әйди

**Фәһемли төшү** Бераз фәһемләү

**ФӘҺЕМЛЕ** *с.* 1) Аңлы, зиһенле, зирәк, тиз төшенүчән; акыллы. *Һәр яңалыкны үзләштерүдә кабилиятле, какшалмаган фәһемле яшьләр өчен тарала торган матбугатта бу акрынлык кичерерлек түгелдер.* Ф.Бурнаш. *Бик тә фәһемле, галәмәт тә зирәк бер хатын белән эшләргә туры килгән иде заманында.* Ф.Баттал

2) Акыл бирерлек, тәҗрибә тупларлык, мәгънәле. *--- роман һәм повестьлар гыйбрәтле, файдалы, җанга ятышлы булсын, тарихи гадел, акыллы һәм фәһемле булсын, дип таләп итәләр.* Г.Ахунов

**ФӘҺЕМЛЕЛЕК** *и.* Фәһемле булу. *Монық [югары уңышлар] өчен кавеменең рухияте мөкәммәл, фәһемлелек дәрәҗәсе югары булырга тиеш.*

*Һәрхәлдә, шуңа омтылу лазем.* Казан утлары

**ФЕВРАЛЬ** *и. лат.* Календарь елының икенче, кыш фасылының өченче ае. *Кичә генә әле февраль иде, Бүген давыл кырга кар ташый. Март аеның нечкә билле җиле Сузылып ятып җиргә кар ашый.* Һ.Такташ

**ФЕДЕРАЛ** *и. рус* 1) Федералист. *Без империячеләр түгел, без федераллар, дия-дия Чечен җирләрен утка тоталар.* Ф.Сафин

2) Дәүләтнең федераль структурасы вәкиле. *Федераллар да аптырап калмадылар, биек таш стеналарга уелган тар тишекләрдән җавап уты ачтылар.* Г.Гыйльманов

**ФЕДЕРАЛИЗМ** *и. фр.* 1) Федерация принципларына нигезләнгән дәүләт төзелеше. *Милләт, этнос, милли мөнәсәбәтләр, федерализм проблемалары да Татарстанның зур гына төркем авторларын җәлеп итте.* К.Гыйззәтов. *Федерация субъектларының чагыштырмача мөстәкыйльлеге федерализмның демократик асылының бик әһәмиятле билгеләреннән берсе булып тора.* Фәнни Татарстан

2) Шундый төзелеш урнаштырырга теләгән, шул карашны яклаган сәяси агым

**ФЕДЕРАЛИСТ** *и. рус* Федерализм яклы кеше, федерализм тарафдары. *«Мин аның федералист, демократ булуына шундый өметләнгән идем», – дип күрсенә Фәндәс ага.* Шәһри Казан

**ФЕДЕРАЛИ́СТИК** *с.* Федерализмга хас, федерациягә мөнәсәбәтле; федерализмга нигезләнгән. *Революциягә кадәрге ситуациягә кайтсак, кадетлар – конституцион демократлар да федералистик рухта булган.* Р.Юныс

**ФЕДЕРАЛЬ** *с.* 1) Федерациягә караган, аның составында булган. *Федераль субъект*

2) Федератив дәүләт идарәсенә караган; дәүләт дәрәҗәсендәге. *Тик, ничек кенә тарткаласаң да, бюджет артмый, киресенчә, федераль хакимият басымы астында елдан-ел юкара, кечерәя генә бара.* М.Авзалова. *Нәзарәт соңгы елларда Федераль үзәкнең эшлексезлеге һәм Дагстандагы хәлләргә битарафлыгының бүгенге низагка китерүен белдерүне үзенең бурычы дип саный.* Сөембикә

3) Турыдан-туры федерация үзәгенә буйсынган. *Район үзәге Иртыш елгасының сул ярында урнашып, сазлык белән әйләндереп алынган, ә каты япмалы федераль юл елганың уң ягы буйлап сузылган.* И.Кашфразыев. *Идел буе Федераль университетының үзәге Казанда урнашкан, Татарстанның берничә уку йорты исә Федераль университет составына кергән.* Кызыл таң

**ФЕДЕРАЛЬЛӘШТЕРҮ** *и.* Федерация принципларына нигезләнгән дәүләт төзү, тигез хокуклы федерация субъектлары төзеп, аларны бердәм сәясәт алып бара торган федераль үзәккә берләштерү процессы. *Россия Федерациясендә хакимиятне кискен үзәкләштерү процессы күзгә ташлана, федерация субъектларының хокукларын бетерү яки чикләү максаты белән, бу хокукларга каршы тоташ һөҗүм алып барыла, моның исә, башка төрле зыяннар китерүдән тыш, реаль федеральләштерүнең соңгы ун елда күренә башлаган үсентеләрен юкка чыгаруы мөмкин.* Фәнни Татарстан

**ФЕДЕРАТИВ** *с. к.* **федералистик**. *Союздаш Республикаларның конституцияләрендә шушы республикаларның федератив корылышы чагылдырылмау кайбер очракларда бу тискәре процессларны көчәйтеп җибәрде.* Т.Миңнуллин. *Милли хәрәкәт җитәкчеләре Россияне киләчәктә федератив дәүләт итеп күрә.* Р.Әмирхан

**ФЕДЕРА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Дәүләт хакимиятендә федераль органнары, бердәм гражданлык, уртак аралашу теле, уртак акча берәмлеге булган сәяси һәм икътисади мөстәкыйльлеккә ия субъектларның берлегеннән гыйбарәт, күпмилләтле илләргә хас дәүләт төзелеше формасы. *Ленинның федерация идеясен эзлекле рәвештә тормышка ашырасы урынга, бер төрле булмаган берәмлекләрнең күп баскычлы структурасы төзелде.* Т.Миңнуллин. *Федерация советы әгъзаларының кимендә биштән берсе, мәгълүм ки, Россия төбәкләре исеменнән эш итәләр.* Фәнни Татарстан

2) Аерым бер мөстәкыйльлеккә ия булган җәмгыятьләр, иҗтимагый оешмалар союзы. *Бүген билбау көрәше буенча илледән артык илдә федерация төзелгән.* А.Гафиятов. *Ул [Мөхәммәтҗанов] Татарстан АССР баскетбол федерациясендә ярышлар үткәрүдә катнаша, судьяларның семинарларын уздыра ---.* Казан утлары

**ФЕЕ́РИЯ** *и. фр. кит.* Гадәттән тыш матур җиһазлар таләп итә торган әкият эчтәлегендәге сәхнә әсәре; гомумән тылсымлы алымнар кертелгән тамаша. *Повесть музыкаль феерия кебек, бик сәнгатьчә иҗат ителгән.* М.Вәлиев

**ФЕЙЕРВЕРК** *и. нем.* 1) Тиз кабынып китүчән махсус катнашмаларны яндырудан барлыкка килә, көлтәкөлтә булып һавага атыла торган төрле төстәге утлар бәйләме, бәйрәм салюты. *Мондый хәлләр кабатланмасын өчен нәрсәләр генә эшләмиләр: һавага аталар, шартлаталар, фейерверклар, хәтта химик матдәләр кулланалар.* Кызыклар дөньясында

2) *күч.* Кызыклы хәлләрнең, бай вакыйгаларның бер-бер артлы тиз баруы, тормышта кинәт барлыкка килгән үзгәрешләр. *Ә сезнең – көн дә бәйрәм, көн дә туй, тормыш түгел, тоташ фейерверк.* Р.Вәлиев

**ФЕЙЕРВЕ́РКЕР** *и. нем. хәрби* Иске рус армиясендә артиллерия составындагы кече командир – унтер-офицер дәрәҗәсе. *Германия гаскәрендә фейерверкер булып хезмәт иткән немец Беран батарея командирлыгына билгеләнде.* Ш.Усманов. *Дивизия начальнигы итеп, Казанда Кораллы октябрь күтәрелешендә актив катнашкан, иске армиянең элеккеге фейерверкеры Якуп Чанышев, ә комиссар итеп шулай ук талантлы шәхес – Абдулла Рәҗәпов билгеләнә.* Д.Шәрәфетдинов

**ФЕЙК** *и. ингл.* **1.** Социаль челтәрләрдә, матбугат чараларында махсус таратыла торган ялган, асылы булмаган хәбәр. *Виртуаль дөньяда фейкларның күп булуын исәпкә алып, без барысын да үз күзебез белән күреп кайтырга булдык.* Кызыл таң

**2.** *с. мәгъ.* Ялган, асылы булмаган, чынбарлыкка туры килми торган. *Казан циркында арыслан кешегә ташланган: фейк видео халыкның котын алды.* Әлмәт таңнары. *Фейк хәбәрләр*

**ФЕЙХОА** *и. порт. бот.* Миртчалар семьялыгыннан уртасы ал, читләре ак төстәге чәчәкле, озынча яисә түгәрәк формадагы кара яшел җимешле мәңгеяшел тропик куак яки агач; шул үсемлекнең җимеше. *Әнә субтропик кыңлекләрдә генә үсә торган гаҗәеп фейхоа.* Ф.Мортазин. *Бер килограмм фейхоада 50–80 миллиграмм йод бар.* Кызыл таң

**ФЕКА́ЛИЙ** *и. лат.* 1) Тизәк, олы хаҗәт калдыгы

2) *махс.* Кеше тизәге һәм сидегеннән торган органик ашлама. *Яз көне фека-*

*лий белән тирес катнашмасын бөтен басуга сибә идек.* Р.Зарипов

**ФЕЛЬДМА́РШАЛ** *и. нем. хәрби* Кайбер армияләрдә иң югары хәрби дәрәҗә һәм шул дәрәҗәдәге хәрби кеше. *Ул фельдмаршалның ризалыгын алды.* Н.Дәүли. *Төз гәүдәле, озын сыйраклы, пөхтә киемле герман армиясе фельдмаршаллары, генераллары танкларын, тупларын тыныч йокыда җәелеп яткан Россия кырларына кертә...* М.Мәһдиев

**ФЕЛЬДМА́РШАЛЛЫК** *и. хәрби* Фельдмаршал дәрәҗәсе

**ФЕЛЬДФЕ́БЕЛЬ** *и. нем. хәрби* Кайбер армияләрдә эчке тәртип һәм хуҗалык эшләрендә рота командирына ярдәм итүче хәрби кеше; өлкән унтерофицер дәрәҗәсе. *Фельдфебель аларның аякларына күз кырыен гына төшерде дә, ул турыда сүзне озайтмыйча, землянкадагы солдатларны окопка куа башлады.* М.Гали. *Аңына килгәч, урысча белә торган дошман фельдфебеле аннан сорау ала башлады.* Т.Әйди

**ФЕ́ЛЬДШЕР** *и. нем.* Махсус урта белемле медицина хезмәткәре, врач ярдәмчесе. *Врач, марля урап торган фельдшерны эшеннән туктатып, кире сүтәргә кушты.* Ш.Камал. *Авылларында фельдшер булып эшләүче Вәзилә апасы дару-майларның нindиен генә алып кайтып карамады...* А.Гыйләҗев

**ФЕЛЬДШЕРЛЫК** *и.* Фельдшер һөнәре, хезмәте. *Керде, түзем генә укыды, диплом алды, шәһәрдә калмады, Язкилде фельдшерлык пунктына мөдир булып кайтты.* А.Гыйләҗев

**ФЕЛЬДЪЕ́ГЕРЬ** *и. нем.* Дәүләт күләмендәге яки хәрби частьлардагы аеруча әһәмиятле, ашыгыч, яшерен кәгазьләрне йөртүче курьер. *Хәзер үк, фельдъегерь аркылы ашыгыч җибәрегез.* Ш.Усманов. *Губернатор почтасын фельдъегерь пар атта махсус көне-сәгате белән җиткергән бит.* Казан утлары

**ФЕ́ЛЬЕТОН** *и. фр.* Көндәлек тормыштагы тискәре күренешләрдән үткен тел белән ачы көлеп язылган кыска күләмле мәкалә. *Сез – яшь язучы, илдә баш күтәргән контрреволюциягә каршы әче фельетоннарның, үткен хикәяләрнең бик кирәк чаклары.* К.Тинчурин. *Фу, каян әйттем әле сезгә, берәр кечкенә фельетон оештырып та, чыгарып та куярсыз әле сез.* М.Фәйзи

**ФЕЛЬЕТОНЧЫ** *и.* Фельетон жанрында язучы, фельетон авторы. *Бер-бер артлы проблемалы мәкаләләр, корреспонденцияләр басыла торды, фельетончылар, Болак турында язып, тапкырлыкта ярышты.* Р.Мостафин. *Редактор эчке телефонның трубкасын күтәреп бер-ике сүз әйтүгә, ишек ачылды, һәм фельетончы кереп басты.* Ф.Баттал

**ФЕЛЮ́ГА** *и. гар. сөйл.* Көньяк диңгезләрдә: кыек җилкәнле (хәзерге вакытта моторлы да), хәрәкәтчән, җиңел кечкенә судно

**ФЕМИ́ДА** *и. гр.* 1) Борынгы грек мифологиясендә бер кулына үлчәү, икенчесенә кылыч тоткан, риясызлык символы буларак күзе томалап бәйләнгән гадел хөкем алиһәсе. *Дөреслек алиһәсе Фемиданы монда утыртып булмый инде. Әйдә, күк йөзеннән генә безгә дөрес юл күрсәтеп, үзенең нурын чәчеп торсын.* Ф.Әһлиуллина

2) *күч.* Суд, суд эшчәнлеге

**ФЕМИНИЗА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Эчке секреция бизләре функциясе бозылу нәтиҗәсендә, ирләрдә хатын-кыз җенесенә хас билгеләр барлыкка килү (мәс., сөт бизләре үсү, тавыш нечкәрү һ.б.)

2) Җәмгыятьтә, иҗтимагый тормышта шәхесне тәрбияләүдә хатын-кыз роленең йогынтысы көчәю. *Адәмнәр арасында ирдарлык бетеп килә. Ир-ат арасында феминизация – «катыншалану» процессы бара.* А.Тимергалин

**ФЕМИНИЗМ** *и. фр.* Хатын-кызларга ирләр белән тигез хокук бирүне максат итеп куйган сәяси-иҗтимагый хәрәкәт. *Феминизм, бер яктан, хатын-кызның иҗтимагый өлкәдә тигезлеген яклаган идеологияне, икенче яктан, иҗтимагый-сәяси хәрәкәтне аңлата.* Ә.Закирҗанов

**ФЕМИНИСТ** *и. рус* Феминизм тарафдары. *Шулай, Зиннәт, үзең гаепле! Замана кешесе, гуманист, интеллигент, феминист булып кыландың да, хәзер инде менә – аша! Акыллы кеше кәләшен чит мужик белән утыртып җибәрәмени?* Аманулла

**ФЕМИНИ́СТКА** *и. рус* Хатын-кыз феминист

**ФЕН** *и. ингл.* Җылытылган һава агымын өрдерү юлы белән чәч киптерү өчен электр җайланмасы. *Чәчләрен (кызганычка каршы, аның чәче бик юка иде) фен белән алты бөртектән алтмыш булырлык итеп кабартты.* Н.Көбәш

**ФЕ́НИКС** *и. гр.* Борынгы грек мифологиясендә, картаеп, үлеме якынлашкач, оясында үзен-үзе яндырып, көленнән яңадан яшәреп барлыкка килү сәләтенә ия булган үлемсез әкият кошы, мәңгелек яңару символы. *Аллаларны һәм аллалаштырылган затларны үлемсез итеп олылаганда, кешеләр кошларны да онытмаганнар, борынгы Мисырда үлемсез Феникс турындагы әкият туган... Калган көлдән күбәләк корты чыга, өч көннән соң, ул тагын фениксқа әверелә.* Могҗизалар энциклопедиясе

**ФЕНОЛ** *и. гр. махс.* Медицинада антисептик һәм йогышсызландыру, сәнәгатьтә синтетик сумала, буягычлар, шартлаткыч матдәләр ясау өчен кулланыла торган органик кушылма. *Суны камыш, күрән, тал куагы үскән сөзәк яр бик шәп чистарта икән, күл камышы, әйтик, пестицидлар, фенол һәм авыр металл кушылмаларын, шул исәптән, терекөмешне дә суырып ала.* Р.Мостафин

**ФЕНО́ЛОГ** *и. рус* Фенология белгече. *Язның кайчан килүе, күпме дәвам итүе, календарь көне, климатик күрсәткечләр һәм фенологлар фаразы белән бер вакытта да тәңгәл килми.* Мәдәни җомга

**ФЕНОЛО́ГИК** *и.* Фенологиягә караган, фенология белән бәйләнешле. *Вегетация чорында тышкы морфологик билгеләре буенча аерылып торган фенологик фазалар бер-бер артлы баралар. Фенологик үсеш җиләк-җимеш үсемлекләренең нәселдәнлегенә салынган.* Бакчачы, яшелчәче һәм умартачы календаре

**ФЕНОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Биологиянең үсемлек һәм хайваннар тормышындагы закончалыклы күренешләрне, аларның дәвамлы кабатланышын ел фасыллары алмашуына бәйләп өйрәнә торган тармагы

**ФЕНО́МЕН** *и. гр.* Бик сирәк очрый торган гадәттән тыш сәләткә ия кеше яки гаҗәп күренеш. *Язучының шәхес буларак үзенчәлеге белән генә бәйләнгән феноменмы бу, әллә татар халкының милләт буларак үсеше тудырган ихтыяҗның чагылышымы?* И.Нуруллин. *Фәнгә Сеченов феномены дип кереп калган һәм актив ял, ягъни Сеченов ялы турындагы тәгълиматка нигез булган тәҗрибәне ул үзе шулай тасвирлый.* Кызыклы психология

**ФЕНОМЕНАЛЬ** *с.* Гаҗәеп, искиткеч, сирәк очрый торган. *Феноменаль музыкаль хәтергә бик күп мисаллар бар: Милий Алексеевич Балакирев концертта Чайковскийның симфоник*

*әсәрләренең берсен ишетеп, ике елдан соң аны авторына яңадан уйнап күрсәтә алган.* Кызыклы психология. *Ростов университетының юридик факультетын тәмамлаган бу егет феноменаль хәтергә ия.* Кызыклар дөньясында

**ФЕНОМЕНАЛЬЛЕК** *и.* Феноменаль булу

**ФЕНОТИП** *и. лат. мед.* Организмның индивидуаль үсеше этабында барлыкка килгән бөтен үзенчәлекләре һәм билгеләре җыелмасы (ул – генотипның мохит белән үзара тәэсир итешү нәтиҗәсе). *Беренче буын гибридларына үзеннән серкәләнергә ирек биреп, икенче буында ул фенотип буенча 3:1 чагыштырмасында таралыш ала.* Р.Зәкиев

**ФЕОД** *и. лат. тар.* Феодалга мирас булып кала торган җир биләмәсе, терлек, акча, дәрәҗә. *Соңрак хәрби хезмәт өчен бирелгән җир биләмәләре мирас итеп күчерелә башлый, латин телендә алар – феодлар дип, ә аларның хуҗалары феодаллар дип аталалар.* Урта гасырлар тарихы

**ФЕОДАЛ** *и. лат.* Феодализм чорында крепостной крестьян хезмәтен эксплуатацияләүче хаким сыйныфка караган җирбиләүче. *Гади халык каны түгелсә дә, сугышны феодаллар игълан иткән.* Р.Мостафин. --- *галим шул чор татар феодалларының эшчәнлекләрен бәяләгәндә --- гомумән кешелеклелек югарылыгыннан торып фикер йөртә.* М.Госманов

**ФЕОДАЛИЗМ** *и. лат.* Җиргә, җитештерү средстволарына тулысынча хуҗа булуга, үз хуҗалыгы булган крестьяннарны шәхси крепостной бәйлелектә тотуга нигезләнгән, колбиләүчелек белән капитализм арасындагы иҗтимагый-икътисади формация. *Ул үз гомерендә өч революция, ике империалистик һәм бер гражданнар сугышы күрде: ярымфеодализм нигезендә корылган татар капиталистик җәмгыятендә һәм Бөек Октябрь социалистик төзелеш шартларында яшәде.* М.Гали. *Кыргызстан исә феодализмнан туптуры социализмга күчеп ята.* Т.Әйди

◊ **Феодализм калдыгы** Феодализм чорыннан калган арттальк. *Ул тәнкыйть иткән, ул мәйданга куйган феодализм калдыгы кешеләре генә түгел, аларның турыдан-туры варислары, сәүдә капиталы буржуасы акрын-акрын мәйданнан югалдылар.* Ф. Сәйфи-Казанлы

**ФЕОДАЛЛА́РЧА** *рәв.* Феодалларга хас рәвештә, феодаллар сыман. *Ә син нәкъ феодалларча хөкем йөртәсең.* Р.Ишморат

**ФЕОДАЛЛАШУ** *ф.* 1) Феодалга әйләнү. *Хәлбуки, ул феодаллашу нәтиҗәсе үзенең читтән кертелгәнлеген һәр почмактан кычкырып тора.* М.Гайнетдинов

2) Феодализм булып формалашу. *Совет чоры тарихы аны феодаллашу процессының мәгълүм дәрәҗәгә ирешүе нәтиҗәсе генә дип карый.* М.Гайнетдинов

**Феодаллаша бару** Әкренләп, эзлекле рәвештә феодаллашу

**Феодаллаша башлау** Феодаллашуга табан бару

**Феодаллашып бетү** Тулысынча феодаллашу

**ФЕОДАЛЛЫК** *и.* Феодализмга хас тәртипләр җыелмасы. *Борынгы ыручылык һәм кучмә патриархальлектән чыгып, болгар бабайлар да акрынлап утрак тормышка күчә, феодаллык тәртипләре җирләшә, кабиләләр берләшү, халыклар төзелүгә юл ачыла.* Н.Исәнбәт

**ФЕОДАЛЬ** *с.* Феодализмга хас булган, феодализм тәртипләренә нигезләнгән. *Ул фольклорны феодаль крепостнойлык калдыкларына каршы көрәштә көчле коралларның берсе итеп алды.* Г.Нигъмәти. *Феодаль таркаулыкның бетерелүе һәм үзәкләшкән дәүләт власте төзелү капиталистик мөнәсәбәтләр килеп чыгуга --- булышлык иткән.* Политэкономия

**ФЕРЗЬ** *и. фар.* 1) Шахмат тактасында туры һәм диагональ буенча теләсә кайсы шакмакка сикерергә хокуклы иң көчле фигура; вәзир. *Яңа уенда да дүрт йөрештә тура белән ферзьне ашатты.* Г.Ибраһимов. *Бу Даут Сөнгатевич ферзь гамбитыннан башлады, шулаймы?* М.Галиев

2) *куч.* Нинди дә булса оешмада, төркемдә җитәкче вазифасын үтәмәсә дә, мөһим урын тоткан, башкаларга йогынтысы көчле булган кеше

**ФЕ́РМА** I *и. фр.* 1) Терлек яки кошкортны аерым туплап үстерү, үрчетү урыны. *Тимергали агай, ферма сарыкларыннан алган йоннан ун пар киез итек бастырып, берничә кыска тун тектерде.* Г.Бәширов

2) Шәхси яки иҗарәгә бирелгән җир өлешендәге аерым хуҗалык кәсәбәсе (предприятиесе). *Эре фермаларда ялланган эшчеләр эшли, алар бөтен авыл халкының 70% чамасын тәшкил итәләр ---.* Чит илләрнең экономик географиясе

**ФЕ́РМА** II *и. фр. тех.* Төзелештә: корылманы күтәреп тора торган, берберсенә беркетелгән борыслардан яки корыч балкадан җыелган корылма; йөртүче каркас. *Аның корыч фермасы тирән чокыр төбенә сыгылып төшкән.* Ш.Усманов

**ФЕРМЕНТ** *и. лат. биол. хим.* Барлык төр тере күзәнәкләрдә дә була, аларда барган биохимик процессларны тизләтә торган, матдәләр алмашында зур әһәмияткә ия булган катлаулы аксым матдәләр. *Кошларның, белгәнебезчә, тешләре юк, ә вакланмаган ризыкны ашказаны эшкәртә алмый. Ашказаны согы һәм ферментларның мөмкинлеге чикле.* Кызыклар дөньясында. --- *органик матдәләр аерым бер ферментлар тәэсире, су һәм һава катнашлыгында төрле сары, карасу төсләргә керәләр.* Җир һәм туфрак

**ФЕРМЕНТА́ЦИЯ** *и. лат.* Махсус төр микроорганизмнар бүлеп чыгарган ферментлар тәэсирендә чимал (мәс., тәмәке, чәй яфракларын) эшкәртүдәге биохимик процесс. *Чәй әзерләүдәге бу бик мөһим процесс ферментация дип атала.* Н.Верзилин

**ФЕРМЕНТЛЫ** *с.* Составында фермент булган, фермент кушылган. *Узган елдан бирле шактый кыю рәвештә химик өстәмәләр, микробиологик һәм ферментлы кушылмалар файдаланыла башлады.* М.Хәсәнов

**ФЕ́РМЕР** *и. ингл.* Ферма хуҗасы, иҗарәчесе, хосусый хуҗалык алып баручы. *Әгәр дә мәгәр, өстән торып, колхозларны таратсалар, бу председательләр югалып калмаячаклар. Аларның бик күпләре бүген фермер була ала.* Т.Миңнулин. *Үз җирләрендә яки лендлордлардан арендага алган җирләрдә авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнүче кешеләрне Англиядә фермерлар дип атыйлар.* Чит илләрнең экономик географиясе

**ФЕ́РМЕРЛЫК** *и.* Фермерлардан торган, шуңа нигезләнгән система; фермер булу. *Фермерлык эшен яхшы белә дип әйтеп булмый, --- әмма өйрәтергә иренмәсәң, начармы-яхшымы, кушканны үти үзе.* Т.Әйди

**ФЕСТИВАЛЬ** *и. фр.* Сәнгатьнең берәр өлкәсендәге уңышларны массакүләм танытуга багышланган чара, тамаша. *Әле күптән түгел генә гөрләп узган «Сандугач» фестивалендә әнисенең шигыренә язылган җыр башкарды.* Г.Камалетдинова. *Конгресс кысаларын-*

*да Татар яшьләренең халыкара фестивале дә үтәчәк.* Сөембикә

**ФЕСТОН** *и. фр.* 1) Бизәү өчен пәрдәләргә, хатын-кыз күлмәкләренә тегелә торган телле-телле яки чук-чук тасма. *Фестоннар куелачак детальләргә аслык салып күклиләр, аңа фестоннар ясалган өлгене күклиләр һәм фестоннар контуры буйлап бөтенесен бергә тискәре яктан кайыйлар.* Йорт эшләре

2) Дулкынсыман яки телле буй формасында эшләнгән архитектура бизәге

**ФЕ́ТИШ** *и. фр.* 1) Гайре табигый көчкә ия һәм тәэсире булганына ышанган җансыз табыну әйбере; пот. *Христиан динендә иконалар, муен тәреләре һәм башкалар – канунлаштырылган фетиш, ислам динендә исә Мәккәдәге Кәгъбә ташы, буддизмда изге Киле фетиш булып хезмәт итә.* Кызыклы психология

2) *күч.* Сукырларча, һичсүзсез ышану, ияргү объекты. *Кием-салымнан фетиш ясамаса да, модадан калышмыйча, европача зәвык белән киенә.* И.Нуруллин

**ФЕТИШИЗМ** *и. фр.* 1) Фетишлар, изге әйберләр культы; потпәрәстлек. *Борынгы мифологик күзаллаулар нигезендә анимизм, тотемизм һәм фетишизм тәгълиматлары ята.* Г.Гыйльманов. *Тотемизм психологиясе фетишизм психологиясе белән, ягъни аерым нәрсәләрне, гадәттә җансыз әйберләрне олылау белән тыгыз бәйләнгән була. Фетишизм – күпчелек диннәрнең иң гомуми һәм даими элементы ул.* Кызыклы психология

2) *күч.* Сукырларча ышану, ияргү. *Кием фетишизмы башлану*

3) Җитештерү мөнәсәбәтләрен матдиләштерү. *Товар фетишизмы*

**ФЕТИШИСТ** *и. рус* 1) Фетишизм тарафдары, фетишларга (*1 мәгъ.*) табынучы

2) *күч.* Нәрсәгә булса да артык ышанып ияргүче. *Модалы картиналар фетишисты*

**ФЕТИШЛАШТЫРУ** *ф.* Фетишка әверелдерү. *Чит ил әдәбиятына һәм сәнгатенә ияреп, бүген еш кына мәхәббәт хисен фетишлаштыру, ягъни аңа сукырларча табыну көчәя башлады.* А.Әхмәдуллин. --- *доходлар һәм аларның чыганаклары бозык, фетишлаштырылган.* Политэкономия

**ФЕТНӘ** *и. гар.* **1.** 1) Хакимияткә каршы оештырылган яшерен кораллы чыгыш, стихияле чуалышлар, башбаштаклык, бунт. *Әлбәттә инде, һәрбер феодаль дәүләттәге кебек үк, Казан ханлыгында хезмәт халкын аяусыз изү дә, авыр салымнар да, фетнә, чуалышлар да булган.* Р.Мостафин

2) Коткы, низаг, тавыш-гауга, җәнҗал. *Һәр фетнәнең башысың, Иблиснең юлдашчысың, милләт башын ашыйсың, хәрәм корсак тидия!* Г.Тукай

3) Ара бозучы, җәнҗал чыгаручы, коткы таратучы кеше. *Өязгә чыкмага боера аларга Халык арасидан фетнә табарга.* Бәет. *Монда кайтып ил казасы, фетнә булган Мостафа.* Г.Тукай

4) Җиңелчә ачуланып әйтелгән сүз. *Ах, фетнә, бу да винтовка тоткан бит.* Ш.Усманов. *Шушы кечкенә генә фетнә шулкадәр тавыш чыгара аламы, дип, тычканга куян гаҗәпләнеп караган.* А.Алиш

**2.** *с. мәгъ.* Ара боза торган, коткы таратучан. *Фетнә сүз сөйләү*

◊ **Фетнә борчасы** *к.* **фетнә** (*3–4 мәгъ.*). *Кем өйрәтте коткы таратырга, фетнә борчасы?!* К.Нәҗми. **Фетнә җиле** Һәртөрле чуалышлар, хакимияткә каршы хәрәкәтләр таралып китәрлек алшартларның булуы, шул хәрәкәттә бербересеннән үрнәк алу. *Фетнә җиле анда да исеп тора, Бәйсез илләр гөмбәдәй үсеп тора.* Ә.Исхак. **Фетнә кубу** Фетнә башланып китү, фетнә күтәрелү. *Әллә аэропортны диңгез уптымы? Монда да бер фетнә әллә куптымы?* Ә.Исхак. **Фетнә салу** Котырту, коткы тарату. *Бер эш кыйлмый, күзен челт-челт йомып, фетнә салып илгә, белер-белмәс көенчә көне-төне сүзләүчеләр күрдек.* М.Гафури. *Фетнә салып йөргән шайтаннарны советларга тотып китер син!* Ш.Бабич

**ФЕТНӘДАР** *и. гар.-фар. иск. к.* **фетнәче** (*2 мәгъ.*). *Үзе – аксак, гакылы – ахмак, фетнәдар, Золымыны изһар кыйлды һәр йирә.* М.Әмин

**ФЕТНӘЛЕ** *с.* Гаугалы, чуалышлардан торган, тынычсыз. *Кем, дисез, бу фетнәле эшләр башы? Кайда бу хаксызга тәфтишләр башы?* Г.Тукай

**ФЕТНӘЛЕК** *и.* Фетнәче булу, фетнәгә этәргеч булу. *Урта Азиядә барган гражданнар сугышы елларында фетнәлек канына сеңгән курбашы советларга каршы гаскәр оештыра.* К.Латыйп

**ФЕТНӘЧЕ** *и.* **1.** 1) Фетнә оештыручы, фетнәдә катнашучы кеше. *1919 елның 14 нче марты көнне ак фетнәчеләр тарафыннан вәхшиләрчә үтерелгән Сәхәбәев Вәҗи, Күкрәков Хәбибрахман һәм башка коммунистларның батырлыгына тирән ихтирам белән багышлыйм.* Ю.Әминов. *Монастырь исә теләсә нинди фетнәчеләргә, шивәчеләргә каршы көрәшү өчен форпост булып хезмәт иткән.* З.Фәтхетдинов

2) *күч.* Җәнҗал куптарырга һәвәс, тавыш-гаугалы кеше

**2.** *с. мәгъ.* 1) Фетнә оештыручы, фетнәдә катнашучы. *Казан тирәсендәге күп татарлар фетнәче башкортларга кушылдылар.* Һ.Атласи. *Рәсәй тарихында нинди генә чуалыш килеп чыкмасын, анда татар катнашмый калмый. Юк, фетнәче халык булганы өчен түгел, бу – шул чуалышта иреккә омтылыш ясау формасы.* Т.Миңнуллин

2) Җәнҗаллы, тавыш-гаугалы. *Я, сиңа нинди җәза бирим, фетнәче карчык?* М.Җәлил

**ФЕТНӘЧЕЛ** *с.* Восстание, фетнә чыгарырга омтылучан, тынычсыз, гаугалы. *Фетнәчел башкортларны тыеп тору нияте белән, Россиянең көньяк чикләрен саклап, күз-колак булып тору өчен, Магнитная крепосте салынды.* Г.Афзал

**ФЕТР** *и. фр.* **1.** 1) Иң яхшы сортлы юка киез. *Башында фетрдан тегелгән кара шапочка.* Ә.Еники

2) Шул киездән тегелгән аяк киеме. *Дускаев суеп каплагандай үзенә охшаган, аягына кечкенә ак фетр белән галошлар кигән.* Ә.Еники. *Өс-башы бөтен: әйбәт бүректән, соры каракүл якалы пальтодан, аягында – каймалы ак фетр.* М.Хәсәнов

**2.** *с. мәгъ.* Шул киездән тегелгән. *Аягымда фетр итек, кем эшләгән ак итеп?* Ш.Маннур. --- *таза-сау егетнең ялтыравык туфли, шәп яшькелт костюм, --- башына фетр эшләпә чәпеп, тәмам купшы кыяфәттә купега килеп керүен өнәмәделәр.* Т.Әйди

**ФЕХТОВА́ЛЬЩИК** *и. рус спорт* Фехтование белән шөгыльләнүче спортчы. *Аның урынына рингта, мәче кебек йомшак кына басып, фехтовальщикны хәтерләткән җиңел-хәрәкәтчән боксчы йөри.* Р.Мирхәйдәров

**ФЕХТОВА́НИЕ** *и. нем.* Шпага, рапира кебек салкын кораллар белән якыннан торып сугышу алымнары системасы һәм шул системага нигезләнгән спорт төре. *Тәтеш атучылары, Казан фехтование осталары Татарстан спортын дөньякүләм аренага чыгарды!* Казан утлары. *Ул, хөкүмәт исеменнән, Казанның шахмат, фехтование, фигуралы шуу мәктәпләренә, ике сәламәтләндерү лагерена автобуслар бүләк итте.* Татарстан яшьләре

**ФЕ́Я** *и. фр.* Кельт, роман халыклары ышануларында кешеләргә игелек яки бәла китерүче, төрле могҗизалар эшләргә сәләтле мифик зат, тылсымчы хатын-кыз, әкият герое. *Имеш, бер корольнең улы туа, һәм бәби туена Авалон атавыннан да берничә фея чакырыла.* Әкият

**ФЁН** *и. лат.* Тау битләвеннән үзәнлеккә таба исә торган коры эссе җил. *Мондый эссе, көйдереп ала торган җилне фён дип йөртәләр, --- фённар Кавказда еш була.* Кызыклы география. *Тирольдәге тау җиле – фён --- үзе белән бик күп уңай ионнар алып килә.* Кызыклы физиология

**ФИ** *ы.* Ризасызлыкны, искитмәүне, ышанмауны белдерү. *– Фи, – диде Тамара, мыскыл катыш көлемсерәү белән, – ә син сатмыйсыңмы, син, аппагым, бөтен яшьлегеңне, бөтен саулыгыңны сатасың.* Н.Гыйматдинова. *Фи, тыңламаган да була, әйтерсең аның сыерын мин бәреп үтергән.* В.Нуруллин

**ФИА́ЛКА** *и. лат.* Миләүшәчәләр семьялыгыннан шәмәхә чәчәк ата торган, вак, куе яшел төстәге сусыл калын яфраклы гөл һәм аның чәчәге; миләүшә. *Фиалкалар төсле болытлардан Ясмин ява, Хәйям, күрәмсең.* Х.Туфан

**ФИА́СКО** *и. ит. кит.* Тулы уңышсызлык. *Бу фиаско искә төшкәндә, әле һаман аркамда салкын тир пәйда була.* Мәдәни җомга

**ФИ́БРА** *и. лат.* 1) *анат.* Мускул җепселе

2) Хлорлы цинк белән эшкәртелгән, җылылык һәм электр изоляциясе, машина детальләре, чемоданнар, тартмалар эшләү өчен кулланылган, тыгыз чүпрәксыман кәгазь катламнарыннан торган прессланган катыргы. *Югары модульле углерод (карбон) җепселләре төзү материаллары өчен иң яхшы фибра булып санала, әмма аларның бәяләре әлегә бик югары.* Төзү материаллары

**ФИБРИН** *и. лат. махс.* Кан оешудан барлыкка килә торган җепселле аксым. *Автор фибрин төере (куерыгы) барлыкка китерә торган молекуляр тәэсир итешүләр белән генә чикләнми, ул табигый антикоагулянтлар тәэсирендә бу процессның вакытта һәм урында чикләүче биохимик реакцияләрен дә --- анализлый.* Фәнни Татарстан. *Тромбоцитлар үзләре генә зур бөке хасил итә алмыйлар. Бөке канда --- фибрин җепселләре аерылып чыгу аркасында ясала.* Кызыклы физиология

**ФИБРОЗ** *и. лат. мед.* Җәрәхәтләнү, ялкынсыну һ.б.ш. сәбәпләрдән җепселле тоташтыргыч тукыманың үсеп китүе. *Саркоидоз кан тамырларыннан һәм фиброз тукымалардан торган шешсыман төерләр барлыкка килеп, аларның үсүе белән характерлана.* Шәһри Казан

**ФИБРО́МА** *и. лат. мед.* Тоташтыргыч тукымадан торган зарарсыз шеш. *Моннан тыш, тавыш бәйләвечләрендә дә фиброма, кытыршы җөй барлыкка килү очраклары ешайды.* Акчарлак

**ФИБРОСАРКО́МА** *и. лат. мед.* Җепселле тоташтыргыч тукымадан яралган яман шеш

**ФИГАН** *и. фар. иск.* Иңрәүсыкрау, моң-зар. *Сугышса, дер дә дер тетрәткән ул бу фани дөньяны, чыгарткан чит халык аузыннан ул күп аһ вә фиганны.* Г.Тукай. *Ишет төннәрдәге былбыл фиганын, аның да бакчы, залим, якты җанын.* Дәрдемәнд

**ФИГУ́РА** *и. лат.* 1) Сын, гәүдә, буй. *Шулай да фигурасы, сыны бик күп татар хатыннарыныкы шикелле зәгыйфьләндерелгән булмавы, карашындагы вәкаре, причёскаланган чәче өстенә куелган калфагының үзенә килешеп торуы белән миндә яхшы хис калдырдылар.* Ф.Әмирхан. *Фигурасы да аның нәфис, сылу гына, кызларныкы кебек диярлек, әмма нечкә йөзе инде таушалган, күз әйләнәсенә дә, ияк тирәсенә дә вак кына җыерчыклар сызылып өлгергән.* Ә.Еники

2) Скульптура, сын. *Шулай да зуррак кисәкләрне кирпеч өйгән кебек өеп, солдатка охшаганрак бер фигура китереп чыгарды.* К.Нәҗми. *Ул, Казандагы опера театрының фойе залларындагы стеналарны гүзәл фигуралар белән бизәп, үз туган туфрагының күркәмлеген арттырды.* А.Расих

3) Очкыч белән идарә иткәндә, биегәндә, тимераякта шуганда һ.б.ш.да башкарган хәрәкәт үрнәге. *Ул, орчык кебек туры гына биеп бара-бара да, бераз чүгә төшеп, тезләрен бер-бер артлы күтәреп-күтәреп, үзенчә төрле фигуралар ясап бии.* Г.Лотфи. *Батыр йөрәкле бу яшь очучы [Дуглас Бейдер] тиз арада үзен бик түбән биеклекләрдә дә югары пилотаж фигуралары ясау остасы итеп таныта.* Кызыклар дөньясында

4) *кит.* Сөйләмнең тәэсирен көчәйтә торган стилистик алым (инверсия, анафора һ.б.). *Андагы күпчелек сүзсурәтләр, стилистик фигуралар бүгенге сөйләм телебезнең дә төп байлыгын тәшкил итәләр.* И.Надиров. *Кайбер шигъри әсәрләрдә анафора стилистик фигура булып кына калмый, ә бөтен әсәрне төзүгә хезмәт итә.* Әдәбият

5) Әдәби образ, герой. *Әсәрдәге Азаматовлар бездә киң җәелгән фигуралардан икәне мәгълүм.* Г.Ибраһимов. *Март аенда уздырыла торган Нәүрүз бәйрәмнәрендә дә Кояш-тәңре – үзәк фигураларның берсе.* Г.Гыйльманов

6) Билгесез яки тану мөмкин булмаган карамчыклар, силуэт, шәүләләр. *Анда дүрт фигура күренә, алар утырганнар булырга кирәк, әнә берсе тәмәке дә кабызды.* М.Гали

7) Зур дәрәҗәле, йогынтылы шәхес. *Варев радист роле белән генә канәгатьләнеп кала торган кеше түгел, ул – бик зур фигура.* З.Фәтхетдинов. *Исламия җәмгыяте эшчәнлегендә үзәк фигуралар икәү: берсе мәхәлләнең имамы, икенчесе – мөтәвәллият рәисе.* И.Надиров

8) Әйләнә-тирәлектә дикъкатьне аеручa тартып, башкалардан аерып алынган әйбер. *Безнең игътибарыбызны җәлеп иткән нәрсә безнең өчен фигурага әйләнә, ә калган барлык нәрсәләр фон була.* Кызыклы психология

9) Шахмат ташы. *Шакир, бүлмәне куе төтен белән тутырып, тәмәкесен тарта-тарта фигураларга карап бераз уйлап тора да, кинәт шатранҗ тактасы өстенә бармагын суза.* Г.Ибраһимов. *Минем фигуралар арасыннан король янына үтеп кереп, --- хурлыклы рәвештә мат куйды.* Г.Афзал

10) *геом.* Яссылыктагы яки пространстводагы йомык сызык белән чикләнгән өлеш (шар, квадрат, өчпочмак); күпнокталар, сызыклар, өслекләр һәм җисемнәр җыелмасы. *Бераздан соң балыклар бу фигураларны аера башлалар һәм өчпочмак куйган чакта, хәтта җим бирмәсәң дә, аның янына килерләр, ә башка фигураларга бөтенләй илтифат итмәсләр.* В.Сабунаев

**ФИГУ́РАЛАУ** *ф.* Фигура барлыкка китерү, фигура ясау. *Фигуралап киселгән төсле кәгазь кисәкләрен альбом битенә ябыштыргач, менә дигән чәчәк букеты килеп чыкты.* Мәгърифәт

**ФИГУ́РАЛЫ** *с.* **1.** 1) Төрле формадагы, тышкы кыяфәте боргалапсыргалап ясалган. *Гади һәм фигуралы кисемнәрне, фасонына карап, я тискәре яктан каеп, я кисемнең кырыеннан ук, я бераз ара калдырып өстән каеп эшкәртәләр.* Йорт эшләре. *Сизрәгән тер-*

*сәкләренә фигуралы ямау салдым әле мин аның – өрәңге яфрагы.* Сөембикә

2) Зифа, матур гәүдәле. *Мин – модалар йорты директоры, яңа киемнәрне киеп тамашачыга күрсәтерлек фигуралы кызлар җыям.* Н.Гыйматдинова

3) Төрле хәрәкәт үрнәкләреннән торган. *Тимераякта фигуралы шуучыларның күрсәтмә чыгышлары бара иде.* Р.Вәлиев

**2.** *рәв. мәгъ.* Төрле фигуралар, хәрәкәт үрнәкләре ясап. *Эштән кайтуга телевизорны кабызып җибәрде, анда фигуралы шуу икән.* М.Мәһдиев. *Ниләр генә кыланмады алар: ул борылышларны үтү, фигуралы йөрү дисеңме, арт белән гаражга керү дисеңме...* Сөембикә

**ФИГУРАЛЬ** *с.* 1) Төрле фигураларга бай. *Фигураль сөйләм*

2) Кинаяле, ишарәле, көчерелмә мәгънәле. *Таянчык туры мәгънәдә – кәләш мәгәлдәктән төшкәндә таяна торган мал, фигураль мәгънәдә – киленнең мораль таянычы булган [мал].* Р.Әхмәтьянов

**ФИГУ́РАЧЫ** *и. спорт* Тимераякта фигуралы шуу белән шөгыльләнүче

**ФИГУРИ́СТКА** *и. рус* Хатын-кыз фигурачы. *Аларның очыштагы хәрәкәтләрен тимераякта иң оста шуучы фигуристкалар да кабатлый алмый.* Ф.Яруллин

**ФИГЪЛИЯТ** *и. гар.* Эшләнгән эшләр, эш-гамәл, эшчәнлек. *Бу тәҗрибә мөдһиш Иван, Петр I, Лука Канашевич һ.б. шыксыз һәм мәкерле шәхесләрнең канлы фигълиятләренә нигезләнде.* Р.Әмирхан

◊ **Фигълияткә чыгару** Тормышка ашыру, чынбарлыкка чыгару. *Ул үзен яңа җылы калушны кигән кебек хис итте һәм дә, шул фикерен фигълияткә чыгарыр өчен, магазинга борылып керде.* Г.Исхакый. **Фигълияткә чыгу** Тормышка ашу, гамәлгә куелу. *Карчыкның якты уйларыннан бере фигълияткә чыгарга да тора иде инде – Гали исемле шома гына бер егетне алар йортка кертә иделәр.* Ш.Камал

**ФИГЫЛЬ** *и. гар.* 1) Эш, гамәл, хәрәкәт. *Төлкенең сүзе илә фигыле арасында нинди мөнәсәбәт бар икән?* Г.Тукай

2) Характер, холык, гадәт, үз-үзен тотыш. --- *шәкертләргә дәрес бирүдән элек, мөгаллим булган кеше үз холкын яхшыртырга вә үз холкы, вә фигыле белән шәкертләргә күчергеч булырга тиештер.* Р.Фәхреддинов. *Бу карт мөлаем, пөхтә кыяфәте, кечелекле фигыле, халкыбызның мәдәни казанышларын киңрәк күрергә-белергә омтылуы белән игътибарымны җәлеп итте.* Т.Әйди

3) *лингв.* Предметның эшен, хәлен процесс рәвешендә белдерә, барлыкюклык, юнәлеш, дәрәҗә, наклонение, заман, зат-сан белән төрләнә торган сүз төркеме. *Татар телендә фигыльләр лексик-семантик ысул белән ясалалар. Бу вакытта фигыльнең мәгънәсе киңәя барып, фигыль нигез фигыль белән үзенең лексик-семантик бәйләнешен тулысынча өзә, һәм, шулай итеп, яңа материаль лексик берәмлек – элекке фигыльнең омонимы барлыкка килә.* Татар грамматикасы

**ФИДА** *и. гар.* Корбан. *Атам-анам йорты өчен булса мең җаным фида, туган-үскән җирем өчен соң тамчы каным фида.* Дәрдемәнд

**ФИДА́ БУЛУ** *ф.* Шәһид китү; корбан булу. *Шаһым, әмма мәслихәт булса, җанымыз юлыңа фида булсын.* К.Насыйри. *Көймә бата; йота торган балык өчен фида булган, мөрәүвәтле бер җан кирәк.* Г.Тукай

**ФИДАИ** *с. гар.* **1.** *к.* **фидакяр**. *Ә син үзең ул фидаи шәкертләрнең бу планнарыннан эш чыгарына ышанасыңмы?* Г.Ибраһимов

**2.** *и. мәгъ.* Үз-үзен корбан итәргә әзер торучы кеше. *Шул юлда башлары киселгән фидаиләрнең үлеп ятуларын күрәм.* Ф.Әмирхан. *Фидаиләр даулый ирек татып ачлыкның ачысын.* Ә.Синугыл-Куганаклы

**ФИДАИЛӘ́РЧӘ** *рәв.* Үз-үзен аямыйча, бөтен көчен биреп. *Әмма алар арасында халыкка хезмәт итү, мәгърифәт тарату өчен фидаиләрчә эшләгәннәре дә күп булган.* Ә.Кәримуллин

**ФИДАИЛЕК** *и.* Фидаи булу, фидакярлек. *Син мәсгудьсең, чөнки фидаилек шәрәфенә ирешкәнсең.* Г.Ибраһимов. *Бабаларыбызның фидаилеге, илбасарлар белән җан аямыйча якалашуының барлык детальләре чагылыш тапкан.* Р.Әмирхан

**ФИДА́ ИТҮ** *ф.* Нинди дә булса максат, эш һ.б.ш. өчен берәр нәрсәдән баш тарту, нәрсәнедер корбан итү, кызганмау. *Һәр милләттә сезнең кеби фидаиләр гыйлем өчен малын, җанын фида итәр.* Г.Тукай

**ФИДА́ КЫЛУ** *ф. к.* **фида итү**. *Мөселманнармы, кяферләрме – үзләрен әҗәл тырнагыннан алып калыр өчен фида кыл.* К.Латыйп. *Шушы мәктәпнең алга китеше өчен фида кылучылар – безнең ата-анабыз, туганыбыз Мөхлисә Бубый, абзыйның җәмәгате Нәсимә вә минем җәмәгатем Хөснефатыйма.* Сөембикә

**ФИДАКЯР** *с. гар.* **1.** Үз-үзен аямыйча, чын күңелдән бирелгән. *Кабанның ихлас һәм фидакяр дуслары табылды, алар, шикаятьләр, матбугатта чыгыш ясаулар белән генә чикләнмичә, зур һәм мөһим эш башкардылар – мәсьәләне тамырдан хәл итү өчен җирлек әзерләделәр.* Р.Мостафин. *Тынычлык, халыклар дуслыгы хакына, аналарыбызның имин картлыгы, сабыйларның якты киләчәге, бүгенгенең фидакяр хезмәте хакына без, солдатлар, сафка басканбыз.* Н.Хәсәнов

**2.** *рәв. мәгъ.* Үз-үзен аямыйча, бөтен көчен биреп. *Аларның [халыкның] бәхете өчен әнә шулай фидакяр көрәшүе, тиңсез таланты Тукайны мәңге онытылмаслык бөек шагыйрь, көрәшче шагыйрь итте.* Г.Бәширов

**3.** *и. мәгъ.* Башкалар өчен үз мәнфәгатьләреннән баш тартырга әзер кеше; фидаи кеше. *Мәгәр үзен хөрмәт иткән җәмгыять шул фидакярләрдән башка газиз телебезне саклый, әдәбиятыбызны дөньякүләм югарылыкта күрсәтә алмавыбызны аңларга тиеш.* Т.Галиуллин

**ФИДАКЯРЛӘ́РЧӘ** *рәв.* Фидакярләр кебек итеп, фидакяр рәвештә. *Фронтта һәм тылда җанын аямыйча фидакярләрчә көрәшүе берсе артыннан берсе күз алдыннан узды.* Г.Бәширов. *Чит өлкәләрдәге милләттәшләребез әле бетмәгән, алар бар, алар әле хәрәкәттә, алар сакланып калу өчен фидакярләрчә эш алып баралар.* Казан утлары

**ФИДАКЯРЛЕК** *и.* Үз-үзен аямау сыйфатларына ия булучанлык. *Язучы исемен йөртер өчен күпме көч, ихтыяр, түземлек һәм, ниһаять, күпме фидакярлек кирәк!* Р.Фәйзуллин. *Дөресен әйтергә кирәк, ханбикәбезнең фидакярлеген, батырлыгын, тәвәккәллеген тулы, дөрес итеп чагылдыра торган әсәрләр әле бездә иҗат ителмәгән.* С.Ибраһимова

**ФИДЕИЗМ** *и. лат.* Дини ышанулар акылдан өстен, дип аңлата торган дини фәлсәфи агым

**ФИДЕИСТ** *и. рус* Фидеизм тарафдары

**ФИДЕИСТИК** *с.* Фидеизмга хас; фидеизмга караган

**ФИДЕИСТЛЫК** *и. к.* **фидеизм**

**ФИДИЯ** *и. гар. дини* 1) *иск.* Үлгән кешенең гөнаһлары ярлыкансын өчен бирелә торган садака, мал, йолым. *Кәҗәсен – фидиясенә, кара тавыгын – гүр садакасына, агын – үзен юган кешегә, бәйрәмнәрдә генә кия торган ак күлмәген үзен кәфенләүчегә бирергә, дип әллә кайчан әйтеп бетергән.* Г.Ибраһимов. *Фидиям дә, гүр садакам да шул булыр.* Ә.Фәйзи

2) Нинди дә булса объектив сәбәп белән (төзәлми торган авыру, картлык һ.б.ш.) рамазан аенда ураза тота алмаган кеше түләргә тиешле садака. *Ураза тота алмаган авырулар фидия садакасын һәр көн өчен 100 сум исәбеннән бирергә яки бер мохтаҗ кешене ашатырга тиеш.* Кәеф ничек?

◊ **Фидия козгыны** Бер җирдән бер җиргә фидиядән өлеш алу максаты белән генә йөрүче кеше. *Миннән чыккан шәкертләр, менә болар кебек, фидия козгыннары булып кала торган булсалар, --- мин андый шәкертләрне мәдрәсәмдә асрамыйм да, укытмыйм да.* Ш.Мәрҗани. *Мин монда фидия козгыны булып килмәдем.* Г.Исхакый

**ФИДИЯЧЕ** *и. дини* Фидия алучы. *Мәетнең сул ягы буйлап, ишектән түргәчә ике рәт булып, дин әһеле – дәверчеләр, фидиячеләр сафланганнар.* Г.Ибраһимов

**ФИ́ЖМА** *и. нем.* XIX гасырда итәкне кабарынкы тоту өчен астан киелә торган, кит мыегыннан эшләнгән каркас; шундый каркасы булган итәкле кием

**ФИЗА́ЛИС** *и. гр. бот.* Паслёнчалар семьялыгыннан җиләге кабырчык пәрдә эчендә булган үсемлек. *Физалис яки Перу чиясе яңа үсемлекләр исәбенә керә.* Яшелчәчелек

**ФИЗЗАРЯ́ДКА** *и. рус* Гимнастика, тән тәрбиясе күнегүләре. *Бөтен җир себерелгән, мал-туар асты тазартылган – бу эшләрне Шакир абзый иртәнге чәйгә кадәр үк башкара, үзенә күрә физзарядка.* А.Расих. *Йокың туйдымы, туймадымы, урыныңнан сикереп тор да пулядай физзарядкага атыл.* К.Латыйп

**ФИ́ЗИК** I *и. рус* 1) Физика фәне белән шөгыльләнүче, физика белгече. *Физик безгә, шаян гына көлеп эндәшеп, Өзеп-өзеп кенә сөйләп бирде Үзенең бик зур яңа идеясен.* М.Җәлил. *Шагыйрь күптән хыялында күктә оча, Йолдызларны сыйпап үтә, айны коча, Барып шушы хыялдагы шигъри юлдан, Эшкә ашыра физик шуны... мең-мең елдан.* Ә.Исхак

2) Физика укытучысы; физика бүлеге студенты. *Ут нәкъ безнең физик булмәсендә.* М.Җәлил

**ФИ́ЗИК** II *с.* 1) Физика закончалыкларына буйсынган, шуның нигезендә барган. *Аралның тагын бер табышмагы бар: бу диңгез, нинди дер сәбәпләр аркасында, Җир әйләнеше процессына бәйле булган физик законнарга буйсынмый.* А.Муранов

2) Физика фәне өйрәнә торган күренешләргә караган. *Физик һәм экономик карталардан тыш, политик карталар да бар.* Чит илләрнең экономик географиясе

3) Тән төзелешенә, тышкы кыяфәткә, организмга бәйләнешле. *Һәм физик, һәм мораль яктан чын мәгънәсендә матур һәм кешелекле кешеләрнең үрнәген без әкиятләрдә бик еш очратабыз.* Г.Бәширов. *Без шулкадәр нык кызып бәхәсләштек: бәхәснең азагы үртәшү, бер-беребезне хурлау, хәтта физик кимчелекләребезне әйтеп көлү белән бетте.* А.Расих

4) Матди, материаль. *Физик төзелеше ягыннан туфрак бик катлаулы полидисперс система булып санала.* Җир һәм туфрак

5) Мускул көченә нигезләнгән, кул хезмәте белән эшләнгән. *Буровойда эшләр өчен бик зур физик көч кирәк, анда эш бик авыр.* А.Әхмәт. *Соңгарак, кайсыдыр бер укытучының киңәше буенча, йокы алдыннан берәр физик эш эшләп керергә гадәтләнде: кар көрәде, утын ярды яки чаңгыда йөрде.* Г.Гобәй

6) Тән сиземләвенә бәйләнгән. *Шул хәл аның күңелендә физик газаплардан да катырак газаплар тудырды.* К.Тинчурин

7) Җенси. *Физик мөнәсәбәт. Физик якынлык*

**ФИ́ЗИКА** *и. гр.* 1) Җансыз материя төзелешен һәм үзлекләрен, аның хәрәкәт формаларын, үзгәрешләрен, табигать күренешләрендәге гомуми закончалыкларны өйрәнә торган табигать фәннәренең берсе. *Химия составларын һәм физика законнарын яхшы белергә кирәк бит.* Ш.Камал

2) Уку-укыту предметы буларак шул фән. *Математика, физика билгеләре – отлично.* А.Әхмәт. *Әйтергә кирәк, рус теленә бәйләнеше булмаган физика, математика кебек фәннәрдән минем эшләр әйбәт кенә бара.* А.Расих

**ФИЗИОКРАТ** *и. фр.* XVIII йөздә Франциядә барлыкка килгән, җирне бердәнбер байлык чыганагы, ә җир эшкәртү хезмәтен – җитештерү хезмәте дип таныган классик буржуаз политик экономия агымы. *Физиократлар байлыкның бердәнбер чыганагы табигать, --- авыл хуҗалыгы дип санадылар.* Политэкономия

**ФИЗИО́ЛОГ** *и. рус* Физиология белән шөгыльләнүче галим; шундый белгечлек табибы. *Узган гасыр азагында Италия физиологы Анджело Моссо кызыклы тәҗрибә ясаган.* Кызыклы психология

**ФИЗИОЛО́ГИК** *с.* Физиологиягә караган. *Организмның төп физиологик функцияләре – сулау, кан әйләнеше, ашкайнату, терморегуляция һәм башкалар.* Кызыклы психология. *Хәзерге вакытта кешедә функцияләре тәүлек әйләнәсендә периодик рәвештә башкарыла торган йөздән артык физиологик система барлыгы ачыкланды.* Могҗизалар энциклопедиясе

**ФИЗИОЛО́ГИЯ** *и. гр.* 1) Организмның функцияләре турындагы фән. *Физиология фәнендә мускуллар гимнастикасы диган төшенчә бар.* С.Сөләйманова. *Физиология кешенең физик һәм психологик резервлары барлыгына һәм аларның шактый зур булуына шикләнми.* Могҗизалар энциклопедиясе

2) Шул функцияләр үзләре һәм алар белән идарә итә торган законнар. *Лишайник катламындагы гөмбә һәм суүсемнең физиологиясе шулай ук мөстәкыйль яшәүче гөмбә һәм суүсемнәдән күп ягы белән аерыла.* Биология. *Һәр кешенең тумыштан ук үз физиологиясе, үзенчәлеге (геннардан ук бирелә), холкы, ягъни индивидуальлеге бар.* Безнең гәҗит

**ФИЗИОНО́МИКА** *и. фр.* Кешенең чырае, мимикасы белән аның эчке әхлакый сыйфатлары, шәхесе арасындагы бәйлелек турындагы өйрәтмә

**ФИЗИОНОМИСТ** *и. рус* Физиономика белгече

**ФИЗИОНО́МИЯ** *и. фр.* 1) Йөз, чырай. *Күзләрең котырган эт күзләре шикелле, физиономияң чабата төсле булганчы эчеп йөр дә, синең исереклегеңне кеше дә белмәсен.* Ф.Әмирхан

2) *күч.* Кемнеңдер индивидуаль йөзе, үзенчәлекле ягы

**ФИЗИОТЕРАПЕВТ** *и. рус мед.* Физиотерапия врачы. *Бервакыт аяк тавышына борылып караса, физиотерапевт Клавдия Сергеевна узып бара.* Г.Әпсәләмов. *Илханның хатыны Түр-*

*кән ханым физиотерапевт булып эшли.* Р.Батулла

**ФИЗИОТЕРАПЕ́ВТИК** *с.* Физиотерапиягә караган. *Физиотерапевтик дәвалау курслары белән беррәттән, көн саен шифалы кымыз бирелүне дә ял итүчеләр югары бәһали.* Кызыл таң

**ФИЗИОТЕРАПИ́Я** *и. гр.* Физик чараларның (хәрәкәт, җылылык, яктылык, су, һава, электр, механик приборлар һ.б.ның) тере организмга йогынтысын өйрәнә торган клиник медицина бүлеге; аларны дәвалау һәм профилактика максаты белән куллану ысуллары. *Магнитлар белән дәвалау методикасы, Курортология һәм физиотерапия үзәк фәнни-тикшеренү институтында врачларның белемен күтәрү буенча үзәк институтның физиотерапия кафедрасында югары бәя алды.* Могҗизалар энциклопедиясе. *Лимфостазны башлангыч чорында консерватив юл – дару, физиотерапия ысулы белән дә сихәтләп була икән.* Сөембикә

**ФИЗКУЛЬТУ́РА** *и. рус* 1) Тән тәрбиясе һәм шуңа бәйләнешле күнегүләр, спорт уеннары. *Лагерьда ял итеп, Камада туйганчы су кереп, физкультура ярышларында бик актив катнашып, вакытның узганын да сизмибез.* А.Расих

2) Тән тәрбиясе күнекмәләрен үзләштерүне максат итеп куйган дәрес. *--- икебез дә физкультурадан сорап, бер сәгать алдан китәбез, яме!* В.Нуруллин. *Чыннан да, бу – алар мәктәбенең физкультура укытучысы, җәен-кышын мәктәпкә я чаңгы, я велосипед белән бара-кайта йөрүче Җәмил Камалов иде.* А.Гыйләҗев

◊ **Физкультура уйнау** Тән тәрбиясе белән шөгыльләнү, күнегүләр ясау. *Без монда физкультура уйнарга чыкмаган.* Г.Нәбиуллин

**ФИЗКУЛЬТУ́РАЧЫ** *и.* Физкультура белән шөгыльләнүче. *Гаскәр үтеп беткәч, Ирек мәйданына физкультурачылар һәм шәһәрнең хезмәт ияләре колонналары килеп керде.* Д.Шәрәфетдинов. *Ел саен август аеның икенче шимбәсендә бөтен Русия буйлап физкультурачы көне билгеләп үтелә.* Татарстан яшьләре

**ФИЗКУЛЬТУ́РНИК** *и. рус к.* **физкультурачы**. *Егет җирән чәчле иде, таза иде, физкультурник иде; урам буйлап чыгып киткән чакларында, карчык аның чуар күлмәк кигән киң аркасына читән аша гына карап кала иде.* Ә.Еники. *Ә менә бу зур курчагым – физкультурник, шуңа күрә көчлерәк ул барыннан да.* Ә.Бикчәнтәева

**ФИЗОРГ** *и. рус* Берәр коллективта, оешмада физкультура эшләрен оештыручы. *Бу юлы аңа физорг Фәрит үз чаңгысын биреп торды.* В.Нуриев

**ФИЗРУК** *и. рус* Физкультура дәресе укытучысы. *Физрук Фәһим, хоккей башлануга өйгә кайтып җитә алу шатлыгыннан, Диләне күтәрен алып, сыйныфтан коридорга ук чыгарып куйды.* И.Сәйфуллин

**ФИКА́РИЯ** *и. бот.* Казаякчалар семьялыгыннан иртә язда сары төстәге ялтыравыклы чәчәк ата торган күпьеллык үлән үсемлек. *Сез аны казаякчалар семьялыгыннан булган фикария белән бутамагыз.* Н.Верзилин

**ФИКЕР** *и. гар.* 1) *филос.* Чынбарлыкның аңдагы чагылышы. *Материя – беренчел, ә фикер, аң, тойгы – бик югары үсеш продуктлары.* М.Абдрахманов

2) Башка килгән уй, фикерләү нәтиҗәсе, фикерләү берәмлеге. *Акыллы сүз, аек фикер, тормышның тирән тәҗрибәсен туплаган аксакаллар фикере бик кирәк хәзерге заманда!* Татар әдипләре

3) Язмача яки телдән әйтергә теләгән төп, әһәмиятле сүз, мәгънәви эчтәлек. *Альманахка кертелгән язучыларның төп җитешсезлеге – төп фикерне ахырга хәтле алып чыга алмау.* М.Җәлил

4) Аң, белем, акыл, дөньяны күзаллау дәрәҗәсе. *Бераз башында фикере барлары, мәктәпләрне, мәдрәсәләрне ислах кылу кирәк, дисәләр дә, фанатик муллалар, үзләренә иярткән юан корсак надан байлар илә һәмишә каршы төшәләр дә торалар.* Ш.Мөхәммәдев. *Үз фикерең белән йөр һәм үз фикереңә карап эш кыл.* Г.Коләхмәтов

5) Исәп, ният, күздә тотылган идея. *Бу фикеремне, бу планымны кабул итәчәкмесең?* Ш.Мөхәммәдев. *Үзенең дә күптән күңелен сызлаткан, их шушыларны әйтергә, дип йөргән фикерләре күп иде.* Ф.Садриев

6) Нәтиҗә, карар, мөнәсәбәтне белдергән, бәяләмә биргән уй, чынбарлыкка мөнәсәбәтне чагылдырган караш. *Бүген, яшьләрнең мәҗлесләреннән башлап, фикерем икегә аерылды.* Г.Коләхмәтов. *Кабан турындагы беренче хезмәтләрдә үк күлләр тезмәсенең Идел белән һичшиксез бәйле булуы турындагы фикер әйтелә.* Р.Мостафин

◊ **Фикер алышу** Берәр мәсьәлә хакында киңәшләшү, төрле яклап тикшерү, төрле якның карашларын тыңлау. *Фикер алышулардан соң закон проекты, кертелгән төзәтмә-өстәмәләрне искә алып, беренче укылышта кабул ителде.* Сөембикә. **Фикергә калу** Аптырап, югалып калу. *Өстәл янында бер карчык әллә ни фикергә калып утыра иде.* Ш.Камал. **Фикергә килү** Берәр карарга килү, нәтиҗә ясау. – *Уйлый торгач, мин, җеп очы Бояр бакчасында булырга тиеш, дигән фикергә килдем, – дип сөйләде малай, үзе дә сизмәстән, мыек үсәсе җирен сыпыргалап.* А.Тимергалин. **Фикергә төшү** *к.* **фикергә килү**. *Шәһәр халкы Галиәкбәр агайның ак яулык белән күзен бәйләп йөргәнен күреп, моның хакында төрле-төрле фикергә төштеләр.* Ш.Мөхәммәдев. **Фикергә чуму** Озак уйлану, тирән уйга бирелү. *Гүяки ул тирән бер фикергә чумды.* Ш.Камал. **Фикердән кайту** Кире уйлау. *Мин әле ул фикеремнән кайтканым юк.* К.Нәҗми. *Илсөяр бабасына булышырга тели, ләкин койрыкны ычкындыруга көймәнең капланууыннан куркып, бу фикереннән кире кайта.* Г.Гобәй. **Фикер җыю** *к.* **фикер туплау**. *Ул фикерләрне мин ун ел җыеп килдем.* А.Шамов. *Кеше турында читләр фикерен җыярга яратмаган Идрис Чәймилованың сүзләренә ныклы игътибар итмәгән иде.* А.Гыйләҗев. **Фикер иләгеннән уздыру** Бик нык, төптән, җентекләп уйлау. *Хәкимҗан бу сүзне фикер иләгеннән уздырып әйтте дә, ятып торган караватында калкынып, үз-үзенә көрсенеп куйды.* Н.Хәсәнов. **Фикер иясе** Зур галим, тирән акыллы, укымышлы кеше. *Хәтта Константин Эдуардович Циалковский кебек алдынгы фикер иясе дә, аерым атомнарда психика башлангычлары бар, дип уйлаган.* Кызыклы психология. *Ләкин ул [Ницше] – күпьяклы фикер иясе, аннан һәркем үзенә юаныч таба ала.* Т.Әйди. **Фикер каршылыгы** Бер үк әйбер турында капма-каршы фикерләр җыелмасы; ихтилаф, конфликт. *Заманында бу әсәр фикер каршылыклары тудырды.* Ф.Галимуллин. **Фикер килү** Башка көтелмәгән идея килү, уй туу. *Кинәт башыма гаҗәп бер фикер килде, һәм ул миңа моңарчы тоелмаган исkиткеч көч бирде.* Г.Нәбиуллин. **Фикер төшү** *к.* **фикер килү**. *--- шул мизгелдә аның башына шук фикер төште.*

Т.Галиуллин. **Фикер туплау** 1) Төрле кешеләрнең яки үзеңнең фикерләрне бергә җыю. *Аның тирәсенә киң җәмәгатьчелек фикерен туплауга көч куйдылар.* М.Җәлил. *Бу дәфтәрдә, – диде ул, – яза торган китабымның төп фикерләре тупланган.* А.Шамов; 2) Берәр нәрсә турында уйлап карап, бер фикергә килергә тырышу. *Аның эш кабинеты киң һәм иркен, ул, нindидер карар кабул иткәнче, фикер туплап ишекле-түрле йөренергә ярата.* Р.Мирхәйдәров. **Фикер туу** *к.* **фикер килү**. *Беренче күрүдә кешегә карата ялган фикер туучан, ә тормыш кино түгел.* Р.Мирхәйдәров

**ФИКЕРДӘШ** *и.* Уртак фикерле кешеләрнең һәрберсе. *Борын фикердәш булган иптәшләре хәзер аны ничек тә аңлый алмыйлар.* Г.Ибраһимов. *Үзенә фикердәш дип уйлаган шәкертләр белән, туры килгәндә, милләтнең артта калуы турында сүз ачылса, Хөсәен мотлакан ул фикергә иттифак итә.* Ф.Әмирхан

**ФИКЕРДӘШЛЕК** *и.* Уртак фикерле булу, бер үк фикердә тору. *Рухи якынлыктан, фикердәшлектән, идея уртаклыгыннан тыш, якташ та, әшнә дә эзләмәде.* М.Кәрим

**ФИКЕ́Р ИТҮ** *ф. к.* **фикер йөртү**. *Югарыга карап фикер ит, түбәнгә карап шөкер ит, диләрме?* М.Мәһдиев

**ФИКЕ́Р ЙӨРТҮ** *ф.* Фикерләү, уйлау; төрлечә уйлап карау, уйлану. *Нәкъ менә фикер йөртү сәләте кешене табигатьнең падишаһы, җирдә булган һәрнәрсәнең иң камил үрнәге итә.* Р.Мостафин

**ФИКЕ́Р КЫЛУ** *ф. к.* **фикер йөртү**. *Фикер кыл: шунда, ди, инде ул үлгән, йөрәгеңне бу шигырь астына күмгән.* Г.Тукай

**ФИКЕРЛӘ́Ү** I *ф.* Уйлау, фикер йөртү. *Йосыф мәхдүмнең әтисе: – Һәр эшнең ахырын фикерләп һәм уйлап эш кылмаган кешенең башы бәла вә кайгыдан чыкмас, – диде бер сөйләшкәндә.* С.Поварисов. *Дөнья хәлләре һәм тормыш итү тәртибе белән җентекле хәбәрдар Гарәфи абый киңәш-корашта ипле һәм дәлилле фикерле иде.* М.Хуҗин

**Фикерләп алу** Бераз, тиз генә фикерләү. --- *һичьюгында, культурасызлык галәмәте була дип, бер фикерләп алсачы.* Б.Рәхимова. *Болайга китсә, бөтенләй башка сөйләшү килеп чыгачагын уйлап, тизрәк ризалыгын бирергә дә шуның белән рәистән котылуы кулайрак буласы хакында фикерләп алды.* Ф.Яхин

**Фикерләп бару** Һәрберсен, бер-бер артлы фикерләү. --- *сурәтләп кенә калмый автор ситуацияне, аның нәтиҗәсен алдан күрергә теләгәндәй, уйлап, фикерләп бара.* А.Шәмсутова

**Фикерләп бетерү** Тулысынча, билгеле бер нәтиҗәгә килеп, фикерләүне төгәлләү. *Мин, әле фикерләп бетереп, нидер әйтергә җыенганда, алар инде сүзсез көч белән җавабын да җиткереп баралар.* Р.Сәгъди

**Фикерләп йөрү** Озак вакыт дәвамында фикерләү. *Ризаэтдин Фәхретдин язганча, куркынычлы вә тәртипсез төшләр, көндез фикерләп йөргән нәрсәләр белән йокыда саташулар рәсүлулла хәдисендә «шайтан уйнавы» дип тәгъбир ителә.* А.Тимергалин

**Фикерләп карау** Сынау, тикшерү, белү һ.б.ш. максатлар белән фикерләү. *Падишаһчык уйлап, фикерләп карады.* Г.Тукай. *И угыл, ата-ана хакларын, әгәр дин йөзеннән күрмәсәң, бары гакылыңа алып фикерләп кара.* К.Насыйри

**Фикерләп кую** Алдан фикерләү яки кинәт бер фикергә килү. *Бармы икән әле адәми затлар арасында шул рәвешле зәгыйфь иманыбызга чиста сулыш өрүгә сәләтле дин әһеле, дип фикерләп куям.* Сөембикә

**Фикерләп тору** Әле, хәзерге вакытта яки даими фикерләү. *Кай заманда бу бакча вөҗүдкә килде, дип фикерләп торганда, бакчаның капкасы янында бер чишмә күрде.* К.Насыйри. *Дәфтәреңә истәлек языйм дип каләмемне алганнан соң, ни языйм дип, бераз фикерләп тордым.* Татар әдипләре

**Фикерләп утыру** Әле, хәзерге вакытта фикерләү. *Хәер, күңеленнән шулай фикерләп утырса да, Закирҗан белән очрашса аңа нәрсә дип әйтәчәген һаман белми иде әле ул.* З.Хөснияр

**Фикерли башлау** Фикерләргә тотыну. *Әйе, хәзер без яши башлаган «... беренче гасыр», «...беренче ел» күп яктан сискәндерә, игътибарыбызны уята, яңача фикерли башларга куша.* М.Вәли-Барҗылы

**Фикерли төшү** Бераз фикерләү. *Димәк ки, кайбер нәрсәләрне ачыклый, фикерли төшәргә, кайбер вакыйгаларны искә төшерергә тиешмен.* Казан утлары

**ФИКЕРЛӘ́Ү** II *и.* Кешенең уйлый алу, фикер йөртү мөмкинлеге. *Язучы фикерләүдә дә мөстәкыйль булмый, ул гавам өчен уртак булган, әзер карашлар суммасы белән эш итә.* Ф.Галимуллин. *Һәм ул аналогияләр логик фикерләү, яңа комплекслы анализ нигезендә ниндидер тарихи симметрия булдыруны таләп итә.* Сөембикә

**ФИКЕРЛӘШҮ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **фикерләү**. *Никадәр чөкердәшеп фикерләшәсе килсә дә, бик үк барып чыкмый әле, Хәниясе ачылып китә алмый.* Н.Хәсәнов

2) Киңәшләшү, үзара фикер алышу, уртаклашу. *Укыту, яшьләр белән эшләү турында фикерләшәсе урында, аңа бәйләнеше юк диярлек нәрсәгә вакыт әрәм итәргә туры килә.* З.Фәйзуллин. *Башка командирлар кебек тыртыртланмыйча, егет белән ипләп, малае белән фикерләшкән кебек сөйләште күрше батальон хуҗасы.* Т.Галиуллин

**Фикерләшә башлау** Фикерләшергә тотыну. *Әлфия Хәсәнова белән театр турында фикерләшә башласаң, аның бөтен тормышы, мәхәббәте, бәхете сәхнә икәнен аңлыйсың.* Т.Нәҗмиев. *Җыелган халык гөж килеп үзара фикерләшә башлады.* Ә.Дусайлы

**Фикерләшә төшү** Тагын да ныграк, күбрәк фикерләшү

**Фикерләшеп алу** Тиз генә, кыска вакыт эчендә фикерләшү. *Мактау актасы каршына тукталып, алдынгыларның фотоларына карый-карый нидер фикерләшеп алалар да янә, паркка ял итәргә чыккандай, ашыкмыйча гына китеп баралар.* Н.Хәсәнов

**Фикерләшеп кую** Алдан фикерләшү. *Кайчак, ир бала туса – атасы, кыз бала булса, анасы исем куша, дип фикерләшеп кую да ярый.* Ислам – татарлар һәм мөселманнар

**Фикерләшеп тору** Һәрвакыт, гел фикерләшү. *Татарстанның Башкортстандагы даими вәкиле Альберт Максютов белән гел фикерләшеп торабыз.* Кызыл таң

**ФИКЕРЛЕ** *с.* 1) Аңлы, акыллы, белемле. *Һидият, чынлап та, киң фикерле кеше түгел.* Ш.Камал. *Фикерле егет, алырга кирәк.* Ф.Садриев

2) Үз уе һәм сүзе булган. *Шәкертләр арасында яңарак фикерле дип белгәннәренә сүз дә салгалаштыра башлады.* Ф.Әмирхан. *Ни өчен син шулай матур, таза кыю фикерле, акыллы кеше?* Д.Аппакова

**ФИКЕРЛЕЛЕК** *и.* 1) Аңлылык. *Аның көтелмәгән мондый тәкъдим-*

*нәрендә дә үзенә генә хас тирән, нигезле фикерлелек, чынлык, мәгънә бар, нык уйланганлык, төптән нигезләнгән дәлиллелекләр, мәсьәләнең асылын сиземләү, алдан сизү бар.* М.Гайнетдин

2) Нинди дә булса фикердә булу. *Ул үз заманында татар әдәбиятында хөкем сөргән артта калганлык, наданлык, иске фикерлелек турында фәлсәфә сатмый.* М.Гали. *Ләкин әдәбиятның идеологик вазифасы мәсьәләсендә төрле фикерлелек күзәтелмәде диярлек.* Ф.Галимуллин

**ФИ́КРӘН** *рәв. гар. иск.* Уй, фикер белән, уй һәм аң ягыннан. *Менә шул сәфаләт зәһәренең актык тамчысына кадәр эчеп, фикрән вә бәдәнән авыру булган бер кеше шәфкатьле вә хәерхаһ бер кулның үзен сөюенә мозаһһәр булмаса, ул кешенең китә торган җире... бетмәк мәзарыдыр.* Г.Тукай

**ФИКРИ** *с. гар.* **1.** Фикерләүгә нигезләнгән, фикерләп беленә торган; уйдагы, фикердәге. *Дини, әдәби, фикри, мәдәни хәрәкәтләр үз эчендә бикләнеп калмый, азмы-күпме читләргә әсәр итә.* Г.Ибраһимов. *Киресенчә булганда, аның эстетик һәм фикри ләззәт бирү көче югала.* Ф.Галимуллин

**2.** *рәв. мәгъ.* Фикерләп, фикер йөртеп, аңда, фикердә булганча. *Гомумиләштерү – предметларда һәм күренешләрдә гомумине фикри аерып кую һәм, шуңа нигезләнеп, аларны үзара берләштерү ул.* Кызыклы психология

**ФИ́КСАЖ** *и. фр. махс.* Плёнкадагы яки фотокәгазьдәге рәсемне беркетү максаты белән кулланыла торган, күбрәк өлеше күкертле натрийдан гыйбарәт булган эремә. *Шулай ук фиксажның яңа булуы шарт.* И.Гайфуллин

**ФИКСАЖЛА́У** *ф.* Фиксаж эремәсендә тоту

**Фиксажлап алу** Тиз генә фиксажлау

**Фиксажлап кую** Алдан фиксажлау

**ФИКСА́ТОР** *и. рус махс.* 1) Нәрсәнең дә булса билгеле бер рәвешен, торышын саклау өчен кулланыла торган прибор, җайланма. *Тышкы яктан кувалда белән катырак сукканнармы, ничектер домкратның штогын тормозда тотучы фиксатор сырдан сикереп чыга.* Ф.Абдуллин

2) Ныгыткыч химик матдә, махсус состав

**ФИКСАТУАР** *и. фр. иск.* Фасонын, торышын саклау өчен, чәчкә, мыекка сөртелә торган махсус крем. *Чигә-яңакларын хушбуйлап, мыегына фиксатуар сөртеп, аның очларын югарыга таба тырпайтыбрак бөтереп куйды.* М.Галәү

**ФИКСА́ЦИЯ** *и. фр.* 1) Билгеләү, ачыклау, беркетү

2) Исемлеккә теркәү, регистрация; язып кую. --- *халык көенең үзенчәлекле, төрле фиксацияләргә авыр бирелә торган бормаларын, моңнарын саклаучы буларак, ул безнең барыбыздан да күбрәк белә иде...* Казан утлары

3) Нәрсәне дә булса (мәс., аяк-кулларны), хәрәкәтчәнлеген бетереп, нинди дә булса торышта катырып калдыру

4) Игътибарны, карашны нәрсәгә дә булса төбәү. *Ә реализм саф фиксация, фактларны тормыш агымыннан гади генә аерып алу пафосыннан башланып китә.* Татар әдәбияты тарихы

5) *биол.* Күзәнәкләрне, тукыманы, әгъзаларны махсус фиксатор матдәләр белән эшкәртеп, аның тере хәлдәге структурасын үзгәрешсез саклау хәленә китерү

6) *фото* Төшерелгән сурәтне ныгыту өчен, плёнканы яки фотокәгазьне фиксаж эремәсендә тоту

**ФИКСА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* 1) Билгеләү, ачыклау, тәгаенләү. *Башка илләрдә рамазан аеның озынлыгы фиксацияләнә.* Мөселман календаре. *Закон нигезендә, эшләмәүче студент көндезге бүлектә укыган вакытта, аның әти-әнисенә фиксацияләнгән түләү арттырып бирелә.* Хезмәт даны

2) Исемлеккә теркәү, регистрацияләү; язып бару. *Метрикаларда фиксацияләнү*

3) Нәрсәнең дә булса хәрәкәтчәнлеген бетерү, бер торышта катырып калдыру, беркетү. *Алар атмосфера азотын фиксациялиләр, туклыклы матдәләрнең туфрактагы запасын туплауга да ярдәм итәләр.* Чәчү әйләнешләре – игенчелекнең нигезе

4) Игътибарны, карашны нәрсәгә дә булса төбәү

5) *биол.* Күзәнәкләрне, тукыманы, әгъзаларны махсус фиксатор матдәләр белән эшкәртеп, аның тере хәлдәге структурасын өйрәнү өчен үзгәрешсез саклау, беркетү

6) *фото* Плёнкага яки фотокәгазьгә төшерелгән сурәтне, фиксаж эремәсендә тотып, ныгыту

**ФИКТИВ** *с. фр.* Рәсми, законлы булмаган, тыелган; ясалма, ялган. *Мин, әле соң түгел, ялгышымны төзәтергә – арабыздагы фиктив никахны суд аша юкка чыгарырга карар бирдем.* Г.Тавлин. *Аерым очракларда якынлык мөнәсәбәтләре күздә тотылмый, ягъни фиктив никах була.* Милләт календаре

**ФИ́КУС** *и. лат. бот.* Тутчалар семьялыгыннан тропик илләрдә үсә торган мәңгеяшел агач һәм шул ук семьялыктан каты, калын яфраклы бүлмә гөле. *Тәрәзә төпләрендә күп төрле вак гөлләр һәм түрдәге ике почмакта киң учарлы ике фикус утыра.* Г.Бәширов. *Язу өстәленнән бирерәк, сул почмакта, куе яфраклы фикус агачы.* Г.Минский

**ФИ́КЦИЯ** *и. лат.* Аерым максатларны күздә тоткан, дөреслеккә туры килмәгән ялган, уйдырма. *Тик бернәрсәгә генә игътибар ителде, төгәлрәге – тойдым: бу йортлар чынбарлыкта, табигатьтә гомумән юк икән. Бу – фикция, уйдырма гына.* Т.Кәримов

**ФИКЪҺ** *и. гар.* Аңлатмасы шәригатьтә булмаган конкрет дини һәм дөньяви мәсьәләләргә карата Коръән, сөннәт һәм иҗтиһадка нигезләнеп нормалар һәм фәтвалар чыгару фәне; шәригатькә нигезләнеп билгеләнгән нормалар һәм кагыйдәләр җыелмасы. *Җыентыкта ислам дине кануннары, фикъһ, астрономия буенча һ.б. язмалар белән беррәттән, гарәп тарихчысы Габарриның хезмәтеннән дә өзек бар.* Казан утлары

**ФИЛ** *и. гар.* 1) Тропик илләрдә үсемлек белән тукланып яшәүче, зур гәүдәле, озын хортумлы, ике озын ак казык тешле имезүче хайван. *Боланның – мөгезе, филнең теше кыйммәт, диләрме әле.* Т.Галиуллин. *Һиндләр, хатын-кызның атлап йөреше белән соклануларын күрсәтергә теләгәндә, аны фил йөреше белән чагыштыралар.* К.Гыйззәтов

2) Шахмат тактасында өченче урында тора һәм диагональ буенча хәрәкәт итә торган фигура; тура. *Ә малай ладьясы, ферзе, аты һәм ике филе белән ябырылып килде дә шыгырдатып кысты.* Г.Афзал

3) *күч.* Олы гәүдәле, авыр хәрәкәтле кеше турында. *Тән үстерсәң, җиһанда, бер дә шиксез, фил булу мөмкин.* Г.Тукай

**ФИ́Л АВЫРУЫ** *и. мед.* Лимфа системасы бозылу нәтиҗәсендә аерым әгъзаларның, гадәттә очлыкларның юанаюы, тиренең һәм тире астындагы күзәнәкләрнең калынаюыннан гыйбарәт авыру

**ФИЛАНТРОП** *и. гр. кит.* Филантропия белән шөгыльләнүче кеше. *Безнең кулдан күп нәрсә килә. Сезнең*

*каршыда филантроп булып кыланырга җыенмыйм.* Т.Миңнуллин

**ФИЛАНТРОПИЗМ** *и. кит.* 1) XVIII–XIX йөзләрдә Германиядә тәрбия, белем бирүдә табигать, тормыш белән бәйләүне максат итеп куйган педагогик юнәлеш

2) *к.* **филантроплык**

**ФИЛАНТРО́ПИК** *с. кит.* Филантропизмга караган, филантропларга хас. *Филантропик тәрбия*

**ФИЛАНТРО́ПИЯ** *и. гр.* 1) *иск.* Кешеләрне ярату, аларга ярдәм итәргә тырышу, гуманлылык

2) Ярлыларга, мохтаҗларга матди ярдәм күрсәтү гамәле. *Меценатлык, шәхси филантропия онытылган илдә мәдәни мохитне тәмам сүнүдән саклаучы да, дәртләндерүче дә чыганак булып дәүләт финанславы кала.* Кызыл таң

**ФИЛАНТРОПЛЫК** *и.* Филантропка хас сыйфатлар, филантропия белән шөгыльләнү. *Чынлап та, үзе явызлык эшләгән кешене ни өчен аяп торырга? Бу нинди филантроплык?!* Ә.Еники

**ФИЛАРМО́НИЯ** *и. гр.* 1) Музыка сәнгатен пропагандалый, музыкаль чыгышлар әзерләү белән шөгыльләнә торган оешма. *Опера, филармония артистлары белән аралашу безгә күңелле иде.* М.Мәһдиев. *– Син кем? – дип сорадым мин аңардан. – Филармония артисты, быргычы, – ди бу.* К.Латыйп

2) Шул оешма урнашкан бина. *Казанның бу борынгы почмагындагы Камал театры, филармониянең концерт залы кебек яңа биналар, реставрацияләнгән «Болгар» кунакханәсе, Г.Тукайга бәйле башка биналар белән матур бер ансамбль барлыкка киләчәк.* Р.Мостафин

**ФИЛАТЕЛИЗМ** *и. гр. к.* **филателия**. *Филателизм белән мавыгу*

**ФИЛАТЕЛИСТ** *и. рус* Филателия белән шөгыльләнүче кеше. *Берәүләр өчен хәзинә – сирәк очрый торган китап, икенчеләр өчен – фотоаппарат, ә филателист өчен – нинди дә булса таушалып беткән бер марка.* Н.Верзилин. *Ял көне Дзержинский клубының бакчасында филателистлар, нумизматлар коллекция алышу бәйрәме үткәрәләр.* М.Юныс

**ФИЛАТЕЛИ́Я** *и. гр.* Почта маркаларыннан, штемпельле һәм маркалы конвертлардан, төрле илләрнең почта эшләре белән бәйле кәгазьләреннән коллекция туплау шөгыле. *Суфия дәфтәр битләренә ябыштырылган иске почта маркалары күреп, филателия белән мавыгучы күрше малаен сөендерергә уйлады.* С.Сөләйманова. *Восстание урамына кадәр барды, филателия кибетенә кагылды.* А.Гыйләҗев

**ФИЛЕ** *и. фр.* 1) Югары сортлы сөяксез сырт ите, билдәмә. *Колхоз базарында, сөякле иткә караганда, филеның бәясе күпкә кыйммәт.* Татар иле

2) Кылчыкларыннан чистартылган балык ите. *Балык филесын озынча итеп турыйлар да тоз, борыч сибәләр, онда әвәләп, үсемлек маенда кыздыралар.* Татар халык ашлары

**ФИЛЁНКА** *и. рус* 1) Рамга куелган юка такта яки фанер. *Парадный ишекне, филёнкасына кадәр асфальт эченә ябышып кату сәбәпле, хәзер ачып та, ябып та булмый, – рус капкадан ихатага үтеп, арт ишектән керделәр.* Х.Сарьян. *Альбомдагы фотоларны алып, рамга куелган пыялага тезде дә, өстенә филёнка ябып, як-яктан беркетте һәм раманы стенага элеп куйды.* Татар иле

2) Стенада ике төсне аерып торган үзгә төстәге тар сызык. *Стенага филёнка үткәрү*

**ФИЛЁР** *и. фр.* Яшерен агент, шымчы. *Ул охранканы, андагы эчке агентураны, тышкы күзәтче филёрларны ишеткән иде.* Г.Ибраһимов

**ФИЛИАЛ** *и. лат.* Эре предприятиеләр һәм учреждениеләрнең үзеннән читтәге, билгеле бер дәрәҗәдә мөстәкыйль эш итә торган бүлеге. *Кай көннәрдә аларның фатирлары офисның бер филиалына әйләнә.* Ф.Яруллин. *Элек ул [Казан энергетика институты] шул профильдәге Мәскәү институтының филиалы иде.* Сөембикә

**ФИЛИГРАНЬ** *и. фр.* **1.** 1) Алтын, көмеш яки башка төрле кыйммәтле металларның чыбыгыннан челтәр сыман итеп үреп эшләү ысулы, техникасы; җепкыр. *Төсле пыяладан инкрустацияләр, скань һәм филигрань куллану – болар һәммәсе дә аларның сәнгатендә татар халык ювелирлык иҗаты нигезендә үсә.* Татарстан яшьләре. *Филигрань остасы. Ростов филигране*

2) Шул техника белән эшләнгән нечкә, нәфис ювелир әйбер; җепкыр. *Мәсәлән, --- иң яхшы филигрань, ягъни, кыйммәтле металл чыбыктан үреп ясалган зиннәтле бизәнү әйберләрен «муза и болгар» --- дип йөрткәннәр.* Фән һәм тел

3) Аерым кәгазьләрдә яктылык аша үтәли күренә торган тамга, билге һәм шундый тамгасы булган кәгазь; су билгесе. *Кәгазьдәге «1816» дигән су билгесе (филигрань) материалның фабрикадан кайчан чыгуын күрсәтә.* Ә.Дусайлы

**2.** *с. мәгъ.* 1) Кыйммәтле металларның бик нечкә чыбыгыннан үреп эшләнгән

2) Пыяла эченә төрле төстәге җепләр белән бизәкләр төшерелгән. *Филигрань ваза*

**ФИЛИГРАНЬЛЫ** *с.* Яктылык аша үтәли күренә торган тамгасы булган, су билгесе булган

**ФИЛИ́ППИКА** *и. гр.* 1) Борынгы грек ораторы Демосфенның Македония патшасы Филипп II нең чын йөзен фаш итеп ясаган сәяси чыгышлары

2) Зур дәрт белән, кызып-кызып ясалган чыгыш. *Хикәят темаларына карата авторның публицистик мактау чыгышлары – филиппикаларыннан, «Мөнәҗәт» һәм «Шикаять» кебек лирик шигырьләрдән төзелгән.* Татар әдәбияты тарихы

**ФИЛИ́СТЕР** *и. нем. кит.* Тар карашлы, кәпрәйгән, үзен һавалы тотучы кеше. *Я ул гаять бөек, я вак; я ул үзирекле, мыскыл итүчән, дөньяга җирәнеп караучы даһи, я хәвеф-хәтәрдән сакланучан, бар нәрсәгә канәгать булган тар филистер.* К.Гыйззәтов

**ФИЛИ́СТЕРЛЫК** *и.* Филистерларга хас сыйфатлар; филистер булу

**ФИЛО́ЛОГ** *и. гр.* Тел һәм әдәбият гыйлеме белгече. *Мин – филолог, рус теле һәм әдәбияты белгече.* Сөембикә

**ФИЛОЛО́ГИК** *с.* Филологиягә карый торган. *Шундый болганулардан файдаланып, филологик проблемага сәяси төс бирелде һәм Русиядә яшәүче халыклар өчен (әлегә) конституцион рәвештә рөхсәт ителгән графика сыйфатында кирилл язуы расланды.* М.Вәлиев. --- *1935–1998 елларда бөтен илдә филологик фәннәрдән 100 меңгә якын диссертация якланган.* Х.Миңнегулов

**ФИЛОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Тел һәм әдәбият гыйлеме. *Чөнки һәр докторлык диссертациясе ул – филология фәненә, аның үсешенә, бу очракта татар филологиясе фәненә саллы өлеш кертү дигән сүз.* Г.Саттаров

**ФИЛО́СОФ** *и. гр.* 1) Философия фәне белгече, шул фән белән шөгыльләнүче кеше. *Шушы максаттан чыгып, шәһәрнең берләштерелгән экология хезмәте булдырыла, аңа экологлар да, биологлар, медиклар, психологлар,*

*архитекторлар, философлар җәлеп итеп.* Р.Мостафин. *Рим философы Сенека дустына, беләсеңме, нинди киңәш бирә: «Син, нәрсә куркыныч, дип сорыйсың, Луцилий, – төркем», – ди.* Н.Гыйматдинова

2) *күч.* Акыл иясе. *Бала һәм яшүсмер чагында бу – минем атам һәм үзебезнең акылга бай, сүзгә тапкыр авыл философы.* Г.Бәширов

**ФИЛОСО́ФИК** *с.* 1) Философия белән бәйле, философия методларына нигезләнгән. *Татар мәгърифәтчеләре, шул исәптән Риза Фәхреддинов та Спинозаның бөтен философик системасын аңлап җиткәннәр, дип расларга җыенмыйбыз.* М.Гайнуллин

2) Тирән мәгънәле, берничә мәгънәви эчтәлеккә нигезләнгән. *Тукайның философик мәгънәсе тирән, эмоциональ көчле һәм бөтен бер эпоханың политик атмосферасын күз алдына бастыра торган --- шигыренә тиң дип әйтергә уйламыйбыз.* Г.Кашшаф

**ФИЛОСО́ФИЯ** *и. гр.* 1) Табигать һәм җәмгыять үсешенең гомуми законнарын өйрәнә торган фән; чынбарлыкка мөнәсәбәтенә бәйле рәвештә философия материалистик һәм идеалистик юнәлешләргә бүленә. *Бик күп билгеләрем арасында иң кадерлесе – философиядән Пронин куйган бишле.* М.Мәһдиев

2) Аерым бер шәхес, төркем, юнәлеш тарафыннан системалаштырылган философик тәгълимат. *Без болар яшендә марксизм философиясе белән таныш булу түгел, Маркcның исемен дә белми идек.* Ш.Камал. *Фейнингерның кешелексез һәм кансыз философиясен Бөек Ватан сугышы елларында фашистлар безнең илебез халыкларына каршы бик теләп кулландылар.* Г.Бәширов

3) Аерым фәннең нигезен тәшкил иткән фәнни методологик принциплар. *Математика философиясе*

**ФИЛО́СОФЛАРЧА** *рәв.* **1.** Философларга охшатып, философлар сыман итеп, фәлсәфи фикерләр кушып. *Әнә шулай философларча уйланып кына утырганда, кинәт ишек кагалар.* М.Мәһдиев

**2.** *с. мәгъ.* Философларга хас, философлар сыман. *Авторның мәгълүматлылыгына, тормыш куйган проблемаларны кую рәвешенә һәм чишү тирәнлегенә, фикерләвенең философларча колачына хәйран каласың.* Р.Рахмани

**ФИ́Л СӨЯГЕ** *и.* Филнең казык теше. *Фил сөягеннән сырлап-бизәп ясалган исәпсез-хисапсыз әйберләр салып калдырганнар.* Н.Фәттах. *Фил сөягеннән һәм агачтан лаклап ясалган художестволы эшләнмәләргә чит илләрдә бик югары бәя бирәләр.* Чит илләрнең экономик географиясе

**ФИЛТӘ** *и. гар.* 1) Ут кабызып яктырту, җылыту өчен, ягулык матдә сеңдерелгән киндер тасма яки шнур (шәм, лампа һ.б.ш.да). *Мостафа лампа пыяласын утыртып, филтәсен күтәрә төшкәч, Данилов яртылаш ачык ишектән коридордагы зәңгәр хәтфә камзуллы кызны күрде.* К.Нәҗми. *Ул [кипкән куян тизәге], туң майга батырып ут төрткәч, филтә вазифасын үти, май төтәмичә генә янып, сыек яктылык бирә.* А.Расих

2) Шартлаткыч матдәгә ерактан ут күчерү өчен кулланыла торган шнур. *Әлтафи – класста иң зур малай, аның кесәсендә һәрвакыт чакматаш белән филтә һәм бакчада үстергән яшел тәмәке булыр.* М.Мәһдиев

**ФИЛТӘЛЕ** *с.* Филтәсе булган. *Өстәл артында филтәле лампа кебек кукыраеп утырган фельдшерны күргәч, кыз барысын да аңлады.* Н.Гыйматдинова

**ФИЛУМЕНИ́Я** *и. гр.-лат.* Шырпы тартмаларының этикеткаларын җыю шөгыле

**ФИЛУМЕНЧЫ** *и.* Филумения белән шөгыльләнүче

**ФИЛЧЕК** *и. зоол.* Озынборынлылар семьялыгыннан озынча башлы, кайбер төрләре авыл хуҗалыгы культураларына зыян китерә торганерткыч коңгыз. *Бөреләр бөртү һәм ачылу вакытында ике-өч тапкыр алма филчеге коңгызларын, җиргә җәймә ябып, кагып төшерәләр.* Бакчачы, яшелчәче һәм умартачы календаре

**ФИЛЬДЕКОС** *и. фр. иск.* **1.** Трикотаж әйберләр туку өчен киҗе-мамыктан эрләнгән берничә җепне тыгыз итеп каткан, нечкә, ефәк шикелле шома җеп

**2.** *с. мәгъ.* Шул җептән эшләнгән

**ФИЛЬДЕПЕРС** *и. фр. иск.* **1.** Иң югары сыйфатлы фильдекос

**2.** *с. мәгъ.* Шул җептән эшләнгән. *Аягын бер-берсенә ишеп утырганда бераз күтәрелә төшкән чалбар балагы астыннан шакмаклы фильдеперс оекбашы күренә.* М.Әмир. *Аякларына тән төсле юка фильдеперс оекларын һәм баскан саен шыгырдап торган, куе кызыл күннән тегелгән каймалы башмакларын киде.* Г.Галиева

**ФИЛЬМ** *и. ингл.* 1) Кино төшерү өчен яктылыкка сизгер катламнан торган юка целлулоид плёнка тасма

2) Шул тасмага төшерелгән сурәтләр тезмәсе, кинокартина. *Шул чорда популяр булган «Тарзан» фильмының героена охшарга тырышып, малай-шалай Сулъяк Болак урамында мунча тирәсендә үсеп утырган биек тирәкләрдән атынып, маймыллар кебек чинашып суга сикерешә идек.* Р.Мостафин. *Алар сугыш турындагы фильм, хроника күренешләренең берсен дә калдырмый карап баралар.* Т.Әйди

3) Кино сәнгате әсәре. *Фильм монтажлау. Фильм төшерү*

**ФИЛЬМОСКОП** *и. гр.* Позитив сурәтне, кинокадрны экранда зурайтып күрсәтү аппараты

**ФИЛЬМОТЕ́КА** *и. ингл.-гр.* Кинофильмнарны җыеп саклый торган урын һәм шул кинотасмалар архивы, кинотасмалар тупланмасының үзе. *Аппарат компьютерына фильмотекадагы фильмнарны берсе артыннан берсен күрсәтә башларга боердылар.* З.Мифтахов. *Россия Дәүләт фильмофонды фильмотекасы*

**ФИЛЬМОФОН** *и. гр.* Киноплёнкага тавыш яза һәм аны кабат тапшыра торган җайланма

**ФИЛЬТР** *и. фр.* **1.** 1) Сыеклыкларны, газларны каты кисәкчекләрдән чистарту, катнашмаларны аерып алу өчен сөзгеч прибор, җайланма, матдә. *Бер предприятиедә суны тондыру буасы да җитеп торса, икенчесендә зарарлы агынтыларны нейтральләштерү кулай, өченчесендә гади, әмма ышанычлы фильтрлар кую зарур.* Р.Мостафин. *Гадәттә туфрак суспензиясе суда тизлек белән утыра, фильтр аша үтми, моны микроскоп, хәтта гади күз белән дә күрергә була.* Җир һәм туфрак

2) Кайбер нурларны, тавыш һәм электромагнитик дулкыннарны аерып үткәрә яки тоткарлый торган прибор. *Акустик фильтр. Яктылык фильтры. Электр фильтры*

3) *информ.* Кулланучыга кирәк мәгълүматларны гына аерып ала торган компьютер программасы

**2.** *с. мәгъ.* Фильтрлый торган, фильтрлагыч. *Фильтр кәгазь. Фильтр матдә*

**ФИЛЬТРАТ** *и. рус* Фильтрланган сыекча

**ФИЛЬТРА́ЦИЯ** *и. рус* 1) Сөзеп чистарту, фильтр аша үткәрү

2) *махс.* Сыеклыкның фильтр аша саркып торуы

3) *куч. тар.* Азат ителгән әсирләр, качып килүче, мигрант, токтарланган кешеләр һ.б.ш.ны тикшерү, төрле төркемнәргә бүлү, төрле урыннарга юнәлтү кебек чаралар. *Фильтрация пунктында ярты ел яттык...* Д.Салихов. *Одессада лагерьга озаттылар, фильтрация дип атала иде, һәр кешедән җентекләп сорашалар, аннан өйгә түгел, Себергә озаталар халыкны. Төп гаеп – әсирлеккә төшү.* Казан утлары

**ФИ́ЛЬТРЛАНУ** *ф.* Фильтр аша узу. *Казанлыкка җир асты юлларында фильтрланган саф сулар килеп торуы, суның парга аз әйләнүе – болар барысы Байкал суының үтә күренмәле, чиста булуын тәшкил итә.* А.Муранов

**Фильтрланып бетү** Тулысынча фильтрлану. *Ул төсне барлыкка китерүче кыска дулкыннар, күзнең сары пигментлы тышчасында фильтрланып бетә алмау сәбәпле, яктылыкны тоя торган күзәнәкләргә кадәр барып җитә.* Татарстан яшьләре

**Фильтрланып җитү** Тиешенчә фильтрлану

**ФИ́ЛЬТРЛАУ** *ф.* Фильтр аша уздыру. *Кодрәтле җир асты аны күпмедер дәрәҗәдә фильтрлап, безгә кабат эчәр су булып ирештерә түгелме?* Татарстан яшьләре. *Билгеле булганча, бөернең төп функциясе – канны фильтрлап, организмнан сидек аша токсиннарны чыгару.* Заман сулышы

**Фильтрлап алу** Тиз генә фильтрлау

**Фильтрлап җиткерү** Тиешенчә фильтрлау

**Фильтрлап кую** Алдан фильтрлау

**Фильтрлап тору** Һәрвакыт, даими фильтрлау

**Фильтрлый башлау** Фильтрларга керешү

**Фильтрлый төшү** Тагын да бераз фильтрлау

**ФИ́ЛЬТРЛЫ** *с.* Фильтры булган, фильтр куелган. *Маня, --- фильтрлы сигарет чыгарып, бик эре кыяфәттә тәмәке тарта башлады.* М.Хәсәнов

**ФИМИАМ** *и. гр. кит.* Төтәгәндә хуш исләр чыгара торган сумала, күнлек. *Монда [Сингапурда] фимиам һәм дуриан исе, Һәрнәрсәгә монда китә исең, Күз камаша монда...* Ә.Рәшит

**ФИН** *и.* Телләре фин-угор семьялыгына караган, нигездә лютеран динен тота торган, Финляндиядә яшәүче төп халык атамасы (үзатамалары – *суомалайсет*) һәм шул халыкның бер вәкиле. *Иртәнге поездга чыгарга уйлап, әлеге үк финнарга кунарга кайттылар.* Г.Исхакый. *Тора-бара Нури фин мәктәбендә укый, татар теле буенча курсларга йөри.* И.Надиров

**ФИНАЛ** *и. лат.* 1) Нәрсәнең дә булса соңгы нәтиҗәсе; ахыргы өлеше. *Син үзеңнең күңелсез финалыңа якынлашасың.* Ф.Садриев. *Начальник, сөйләшүнең тәмамланганын белгертеп, өстәл читендәге төймәгә басты. Мин мондый финалга әзерләнмәгән идем.* М.Юныс

2) Музыканың яки сәхнә әсәренең ахыргы өлеше. *Һәрхәлдә икенче актның финалы бик көчле һәм дулкынландыргыч булырга тиеш.* М.Җәлил. *Финал өлешендә ачларга ярдәмгә азык олаулары килү күренеше өстәлә иде.* Ф.Галимуллин

3) *спорт* Спорт ярышларының җиңүчеләрне ачыклый торган соңгы этабы. *Әгәр җиңсәләр, Түбән авыллар республика ярышларына финалга чыгалар.* А.Гыйләҗев. *Анда [«Автоледи – 99» конкурсында] 78 хатын-кыз катнашты, шуларның утыз өче финалга узды.* Сөембикә

**ФИНАЛИСТ** *и. рус к.* **финалчы**. --- *без 18 августта Алматыда урнашкан АКШ илчелегеннән 40 финалист океан артына юнәлдек.* Сөембикә

**ФИНАЛЧЫ** *и. спорт* Финалга чыгучы. *Икенче финалчы бүген Сочида – Мексика һәм Германия командалары очрашуыннан соң ачыклана.* Туганайлар

**ФИНАНС** *и. фр.* 1) Халык хуҗалыгында товар-акча әйләнешенең бер элементы буларак акча средстволары. *Дәүләт банкларында, бүтән төр финанс органнарында булдым.* Р.Фәизов. *Сметадан тыш сукыр бер тиен дә тота алмыйбыз, финанс ревизияләре, халык контроле белән ни эшләргә кушасыз тагын?* Р.Мостафин

2) Гомумән акча; акча эшләре. *Тукта, алаен алай да, минем финанс хәлләрем ничегрәк икән соң.* А.Расих. *Кабан проблемасы техник якка яки финанс мәсьәләләренә генә кайтып калмый, иң әүвәл бу – аңлылык, вөҗдан мәсьәләсе.* Р.Мостафин

**ФИНАНСИСТ** *и. рус* Халык хуҗалыгында товар-акча әйләнеше операцияләрен башкаручы кеше, финанс фәннәре белгече. *Гаҗәп инде, нәкъ менә Драйзерның финансисты кебек...* Ә.Еники. *Бер якта – күккә ашкан пыяла һәм металл йортлар, буржуазия вәкилләре – бизнесменнар, гангстерлар, финансистлар хуҗа булган зиннәтле виллалар, ә икенче якта – эшсезләр, негрлар яши.* А.Муранов

**ФИНАНСЛАНУ** *ф.* Матди яктан тәэмин ителү, махсус адреслы акча күчерелү. *Совхозның ул вакытта ук дәүләт тарафыннан финанслануы аркасында, алардагы хәл колхоздагыга караганда өстенрәк, акрын булса да төзелеш тә бара.* Г.Ахунов. *Бюджет-иминият моделе эшмәкәрләрнең, хезмәт ияләре – гражданнарның максатчан взнослары һәм дәүләт субсидияләре исәбенә финанслана.* Татарстан

**ФИНА́НСЛАУ** *ф.* Акча күчерү, матди тәэмин итү. *Әлеге льготалы чыгымнарны финанслау территориаль хастаханә һәм даруханә кассаларына йөкләнгән.* Сөембикә. *«Иркеннефть» идарәсе Лениногорск, Әлмәт, Бөгелмә районнарында 9 мәчет салуны финанслаган.* Татарстан яшьләре

**Финанслап бару** Эзлекле рәвештә финанслау

**Финанслап җиткерү** Тиешенчә, тулысынча финанслау. *Шуңа күрә хәзерге финанслап җиткермәү вакытында бу статья ел саен якланмаган килеш кала.* Заря

**Финанслап тору** Һәрвакыт, даими финанслау. *Мин үзем сезне аз-азлап финанслап торырмын.* Г.Каюмов

**Финанслый башлау** Финансларга тотыну. *Шулай итеп, Татарстан мәдрәсәләре тарихында беренче тапкыр Диния нәзарәте үзенең мәгариф системасын финанслый башлый.* Ислам – татарлар һәм мөселманнар

**ФИНИКИ́ЯЛЕ** *и.* Антик чордагы Финикия дәүләте кешесе. *Ливанлылар әле хәзер дә үзләрен гарәпләр дип түгел, финикиялеләр дип йөртәләр.* С.Сөләйманова

**ФИ́НИШ** *и. ингл.* 1) *спорт* Спорт ярышларының ахыргы, хәлиткеч өлеше, ахыргы пункты. *Финишка беренче булып килгән Мәрьямне халык чорнап алган иде.* М.Шабай

2) Эшнең ахыры, нәтиҗәсе. *Иске ел поезды финишка вакытында килеп өлгерәме-юкмы, безнең язмыш шуңа бәйләнгән.* Р.Вәлиев. *Ярыш нәтиҗәләрен карыйм, ...тегеләр алда, мине сикереп узганнар. Булмый икән бу, дип уйлаган идем, һәм дөрес чыкты: финишта – алар беренче.* Н.Хәсәнов

**ФИ́НКА** *и. рус* 1) Кыска, киң йөзле, үткен очлы фин пычагы. *Шул вакытта ул кулын Иреккә таба юнәлтте, һәм аның учыннан чырт итеп финка килеп чыкты.* Ф.Садриев. *Сәет, наганын төбәгән килеш, күзләрен семафордан алмыйча чүкте дә сул кулы белән финканы алды.* И.Салахов

2) Арты һәм ян-яклары аска кайтарылып төшерелә торган, мех кырпулы түгәрәк җәлпәк бүрек

3) Гәүдәгә зур булмаган төньяк ат токымы. *Финның арбасына әйберләрне төяште дә, юлга чыктылар, түгәрәк кенә, кечкенә генә финка юлдан йомгак кебек тәгәрәргә тотынды.* Г.Исхакый

**ФИ́ННА** *и. нем. зоол.* Тасма суалчанның личинка фазасы. --- *кеше организмына финна пешеп җитмәгән ит белән керә һәм инде бирелә җенси өлгергән формага әверелә.* Биология

**ФИННОЗ** *и. мед.* Кешеләрдә яки хайваннарда тасма суалчан личинкалары – финналар белән зарарлану нәтиҗәсендә килеп чыккан авыру

**ФИННО-УГРИЗМ** *и. рус грам.* Нинди дә булса телдә фин-угор телләреннән алынган сүз яки гыйбарә. *Татар телендә финно-угризмнар урта диалект вәкилләрендә ешрак кулланыла*

**ФИННО-УГРИСТ** *и. рус* Финно-угристика белгече. *Тюркологлар һәм финно-угристлар конференциясе*

**ФИННО-УГРИ́СТИКА** *и. рус* Фин-угор телләрен, әдәбиятын, культурасын, тарихын, көнкүрешен һ.б. өйрәнә торган фәннәр җыелмасы. *Хәзерге финно-угристиканың үсеш юллары*

**ФИ́Н ПЫЧАГЫ** *и. к.* **финка** (*1 мәгъ.*). *Чалдунов --- сандыгыннан фин пычагы алып, итек кунычына кыстырып чыкканда, Хәсән, тимер таягы белән уйнап, аны көтеп тора иде.* Ш.Усманов

**ФИНТ** *и. ит. спорт* Алдау хәрәкәте, хәйләле һөҗүм. *[Тупка] Тибәм дигәндә генә, бер җитезе финт ясап өлгерде, мин һавага тибеп калдым.* Казан утлары

**ФИН-УГОР** *и.* Урал телләре семьясын тәшкил иткән, борынгыдан уртак культурага ия булган мари, удмурт, мордва, коми, саам, карел, манси, фин, эстон, мажар һ.б. кайбер халыклар кергән этник төркем һәм шул төркемнең бер вәкиле; угро-фин. *Шулай итеп, төп халкы фин-угорлар һәм татарлар булган Суздаль, соңрак Владимир кенәзлеге Русиянең башлангычы була.* И.Хуҗин. *Мич, ужым, гөмбә, әвен сүзләре – урыстан, миләш, бүкән, пошч – фин-угор телләреннән, мәктәп, фикер, дошман, дус сүзләре гарәп-фарсыдан кереп, безнең көндәлек аралашуыбызга хезмәт итә икән.* Т.Әйди

**ФИ́НЧА** *рәв.* Фин телендә; финнарга хас булганча. – *Мин сине монда финча ашатырга уйладым, – дип, беренчегә салкынча тозлы гөмбә бирде.* Г.Исхакый

**ФИОРД** *и. норв.* Тар, озын, тирән, еш кына тармакланып киткән текә биек ярлы диңгез култыгы. *Шхералар диңгезнең яр буе өлешен зур дулкыннардан саклый торган барьер хезмәтен үтиләр, яр буйларында һәм фиордларда суднолар йөрешен куркынычсыз итәләр.* Чит илләрнең экономик географиясе. *Скандинавия фиордлары*

**ФИРАК** *и. гар. иск.* 1) Аерылу, аерылышу. *Фирак эстәрме һич бер кемсә сәннән.* Г.Тукай

2) Китеп бару. *Кавышу бәһшәттер, ләкин дәһшәт җәһәннәмдер фирак.* Ш.Бабич

**ФИРАСӘТ** *и. гар.* Сизгерлек, зиһенлелек, үтә зирәклек. *Дүрт яшендә дан булды, фирасәте фаш булды.* Идегәй

**ФИРӘЗӘ** *и. к.* **фирүзә**. *Кулындагы йөзекнең фирәзә кашы белән төстәш күзләре ярым оялып, ярым шаяртып карый беләләр.* К.Нәҗми. *Аның эчендә өч алтын йөзек, дүрт чылбыр, медальон, фирәзә кашлы алка – барысы да алтын.* М.Насыйбуллин

**ФИРГАВЕН** *и. гар.* 1) Борынгы Мисыр хөкемдарларының исеме, титулы. *Аллаһ Тәгалә Нух пәйгамбәрне туфан суыннан, Ибраһим галәйһиссәлләмне – уттан, хәзрәте Мусаны – Фиргавеннән, Мөхәммәд Мостафаны мөшрикләр тозагыннан коткарганы кебек, Гайсә хәзрәтне дә яһүдләр кулыннан коткарды.* Х.Чантай. *Муса пәйгамбәр яһүдиләрне Мисырдан алып киткәч, Фиргавен гаскәре белән аларны куа, ләкин Аллаһы кодрәте белән диңгезгә батырып һәлак ителә.* Милләт календаре

2) *куч.* Каты күңелле, усал кеше. *Фиргавен икәнсең син һәнүз.* Г.Тукай. *Тиздән барлык явыз мәкерләрегезне башыгызга капларбыз, йөзе кара фиргавен токымнары.* К.Нәҗми

**ФИРДӘВЕС** *и. фар.* Оҗмах, җәннәт бакчаларыннан берсе. *Ник җиреңне, бар җиреңне фирдәвестәй итмәдең?* Һ.Такташ

**ФИРЕШТӘ** *и. фар. сөйл. к.* **фәрештә**. *Йорт алдына чыккансың, күктә йөзгән фирештә.* Дастан

**ФИРКА** *и. гар.* 1) Төркем, группа. *Хәбәр юк ханга, бер көнне әтәч тавышлана тагын, менә тиз-тиз икенче фирка гаскәр сафлана тагын.* Г.Тукай. *Фикер каршылыкларын, шәхси симпатия-антипатияләрне, төрле фирка ызгышларын бер читкә куеп, халкыбызның язмышын, милләтебезнең киләчәген кайгырту өчен җиң сызганып эшкә керешик.* Т.Әйди

2) *сәяси* Партия. *Һәр нотыгында ул үзенең фирка эшенә бирелгән намуслы кеше булуы, яшьләргә чиксез мәхәббәте турында сөйләргә ярата.* Т.Галиуллин. *Тамчы таш тишә, 1978 елда Һиллари үзенең җефетен Демократлар фиркасыннан Арканзас штатының губернаторы итте.* Сөембикә

**ФИРКАЛЫ** *с.* Партияле. --- *һәр фиркалыны төнге бердә сискәндереп уяткан, залим Сталинның мәкерле хыялы тудырган партия комиссиясе кебек байтак күзәнәкләр яшәүдән туктады.* Т.Галиуллин

**ФИРКАЛЫЛЫК** *и.* Партиялелек, партияле булу. *Сыйнфыйлык, фиркалылыкка өстенлек бирелү миллилекне чикләү белән бергә үрелеп барды.* Ф.Галимуллин

**ФИРКАЧЫ** *и.* 1) Аерым группага, төркемгә караган кеше. *Аны [докладны] тикшерүдә катнашырга теләк белдергән унтугыз фиркачының унберен тыңлагач, урыннан килгән тәкъдим нигезендә, фикер алышу тәмамланды.* Т.Галиуллин. *Аның [юрист Островның] чыгышын фиркачылар шик астына алалар.* Г.Ахунов

2) Кайсы да булса партиянең әгъзасы

**ФИРКАЧЫЛЫК** *и.* Төркемнәргә, партияләргә бүленгәнлек, таркаулык. *Без бит барыбыз да татар милләтен тәшкил итәбез, фиркачылык булырга тиеш түгел.* Сөембикә

**ФИ́РМА** *и. ит.* Юридик хокукларга һәм үз сәүдә маркасына ия булган сәүдә яки сәнәгать предприятиесе. --- *Николаев шәһәрендәге «Ал җилкәннәр» фирмасының кремнары шифалы икән, дип ишетеп, аларны эзләп таптылар, берсенең дә файдасы тимәде.* А.Гыйләҗев. *Чималның бөтенесен диярлек чит ил фирмалары сатып алалар һәм чит илләргә чыгаралар иде.* Чит илләрнең экономик географиясе

**ФИРҮЗӘ** *и. фар.* **1.** 1) Фосфатлар классыннан зәңгәр яки яшькелт төстәге минерал асылташ. --- *Казан таҗы каралтылган көмешле алтыннан эшләнгән: аңарда бер якут ташы, 12 ал якут бөртеге, 30 фирүзә, 14 энҗе бөртеге, 22 лал --- патшаның хәзинәләр саклавычына 1552 елда керде.* Сөембикә

2) Зәңгәр төс, шул таш төсе. *Күзләре – балкып торган фирүзә, килешле итеп иннек яккангамы, яңакларына сыек алсулык җәелгән.* Т.Әйди

**2.** *с. мәгъ.* 1) Шул таш белән бизәлгән, шул таштан торган. *Алтын таҗ һәм гүзәл фирүзә тәхет, башка күп мал – сизсен, дип, Сөхрәб бәхет.* Мирас

2) Шул таш төсендәге. *Егерме көн эчендә фирүзә диңгезләрне, Төркия – Истанбулларны, Гарәбстан – Мисырларны урап әйләнде дә кайтты.* Р.Хисмәтуллин

**ФИСГАРМО́НИЯ** *и. нем. муз. иск.* Яңгырашы белән органга тартым, клавишлы тынлы музыка коралы. *Шәфика иртәгесен, өйдә кеше югында, фисгармония янына килеп утырды да кичә әнисе җырлаган көйне уйнап җибәрмәкче булып азапланды.* Казан утлары

**ФИСК** *и. лат.* 1) Борынгы Римда император казнасы (дәүләт казнасына каршы куелган); IV гасырдан бөтен керемнәрне, җыемнарны һәм шуннан түләүне үз эченә алган бердәм гомумдәүләт казнасы

2) Дәүләт казнасы

**ФИСКАЛ** *и. лат.* 1) Россиядә Пётр I тарафыннан кертелгән финанс һәм суд эшләренә күзәтчелек итүче дәүләт чиновнигы

2) Доносчы, әләкче

**ФИСКАЛЬ** *с.* Фискка кагылышлы; дәүләт казнасы мәнфәгатьләренә хезмәт итә торган. *Соңгы рейд вакытында дәүләт казнасына законда каралган фискаль түләүләр буенча 2286 мең сум әҗәт кайтарылган.* Хезмәт даны. *Фискаль чек. Фискаль салым*

**ФИ́СТУЛА** *и. лат. мед.* 1) Куыш әгъзада тар үтәли яра

2) Эчке органнан тышка чыгарылган трубка, көпшә

**ФИСЫК** *и. гар. иск.* Начар, бозык юл; начар эшләр, азгынлык. *Нәфес арзусына әсир улып, фисык вә фәсад атына атланыр.* К.Насыйри. *Нишләп фисык булсын, алар руза тотарга ният итеп ятмыйлар бит, шуңа күрә алар руза бозучы булмыйлар.* Ф.Әмирхан

**ФИСЫ́К-ФӘСАД** *җый. и. гар.* Һәртөрле бозыклык. *Һәрбер имамга, үзенең мәхәлләсендәге фисык-фәсадны тыяр өчен, гаеплеләрне яткырып суктыру хокукы бирелсен.* Г.Ибраһимов. *Бу фисык-фәсадның оясы – Галимҗан хәзрәт мәдрәсәседер.* М.Галәү

**ФИТИЛ** *и. гар. к.* **филтә**. *Лампа фитиленнән кәгазьгә тоташкан зур ялкын аларның йөзләрендә, су өстендәге таң кызыллыгы кебек, саклык белән чагылды.* К.Нәҗми. *Забой алдына үрмәләп, фитил очына ут кабыза да тиз генә китеп бара.* Ш.Камал

**ФИТИН** *и. гр.* Күп үсемлекләрдә очрый торган фосфорның органик кушылмасы (медицинада фосфор препараты буларак кулланыла). *Фитин киндер орлыгыннан ясала*

**ФИ́ТНЕС** *и. ингл.* 1) Сәламәт яшәү рәвеше. *Беренчедән, хәзер модада булган органик ризык, махсус меню, фитнес туклану, биопродуктлар ашасак, безгә идеаль фигура һәм нык иммунитет вәгъдә итәләр.* Кәеф ничек?

2) Кеше организмының тышкы физик тәэсирләргә каршы тора алу әзерлеге

3) Организмны ныгыту максатын куйган күнегүләр җыелмасы. *Биредә алар иң элек фитнес белән шөгыльләнде, аннары бассейнда йөзде.* Кайбыч таңнары

4) Махсус әзерлекле инструкторлар ярдәме белән шундый күнегүләр ясый торган махсус җиһазландырылган урын; зал, клуб. --- *үзләре һәм аларның балалары блат белән блатной вузларга керсен, чит илләрдә белем алсын, инглизчә укысын, фитнесларга йөрсен, Кипрда яисә Гарәп Әмирлегендә ял итсен, кыйммәтле иномаркаларда чапсын...* Р.Миңнуллин

**ФИТОБАР** *и. гр.-ингл.* Шифалы үләннәрдән әзерләнгән чәйләр, төнәтмәләр тәкъдим ителәэ торган кечкенә кафе, ресторан. *Сарай-замокның ишеге өстендә «Чәйханә, фитобар» дигән язуны күреп, егетләр эченә кереп карарга булдылар.* Р.Мирхәйдәров. *Бакчаның үз остаханәсе, үз музее, бассейны, фитобары... гомумән, бары да заманча.* Сөембикә

**ФИТОДИЗА́ЙНЕР** *и. ингл.-гр.* Интерьерларны тере яки ясалма үсемлекләр белән бизәүче белгеч

**ФИТОЗАЛ** *и. гр.-фр.* Даруханәләрдә шифалы үләннәр һәм алардан эшләнгән төнәтмәләр сата торган зал

**ФИТОКОСМЕТОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Тән тиресен тәрбияләү өчен, үсемлек эшләнмәләреннән файдалана торган косметология бүлеге

**ФИТО́НИМ** *и. гр.* Үсемлекләр белән бәйле атамалар. *Бу авылларга атамалар фитонимнарга мөнәсәбәтле рәвештә бирелгән.* Ф.Гарипова

**ФИТОНЦИД** *и. гр.-лат.* Кайбер үсемлекләрдә (мәс., суган, сарымсак, артыш һ.б.да) барлыкка килә торган, микроорганизмнарның үсешен туктатырга, хәтта аларны үтерергә дә сәләтле булган биологик актив матдә. *Бер гектар артыш куаклыгы бүлеп чыгарган фитонцид бер зур шәһәрнең барлык чүп ящикларын дезинфекцияләргә җитә.* Робинзон эзләреннән. *Галимнәр шомырт тамырындагы фитонцидларның микробларны, бөҗәкләрне үтерә алуын да ачыклаганнар.* Мөселман календаре

**ФИТОПЛАНКТОН** *и. гр.* Сулыкларның өске, кояш яктысы җиткән катламында яши торган, фотосинтез процессын барлыкка китерергә сәләтле вак суүсемнәр

**ФИТОПРЕПАРАТ** *и. гр.-лат.* Шифалы үләннәрдән ясалган катнашмалар, дәва өчен әзерләнгән дару үләннәре. *Фитопрепаратның профилактик йогынтысы һәркем өчен файдалы.* Сөембикә

**ФИТОТЕРАПЕВТ** *и. гр.* Фитотерапия белгече. *Коточкыч хәлдән [шартлаудан] соң җитештерүне тергезү өчен, фитотерапевт Михаил Гордеев халыктан ярдәм сорый.* Кызыл таң

**ФИТОТЕРАПИ́Я** *и. гр.* Үләннәр белән дәвалау. *Фитотерапияне киң куллануга әле һаман да үсемлектәге тәэсир итүче (биологик актив) матдәләрнең хәзерге биохимик методлар ярдәмендә җитәрлек өйрәнелмәве комачаулый.* Урман аптекасы. *Билгеле булганча, халык медицинасы буенча дәвалану популярлашып бара, әйтик, фитотерапиягә игътибар артты.* Сөембикә

**ФИТОФАГ** *и. гр.* Үсемлек белән генә туклана торган җан иясе (мәс., партояклылар, күп кенә бөҗәкләр)

**ФИТОФТО́РА** *и. гр.* Үсемлекләрдә паразит буларак тереклек итә торган гөмбә. *Бер үк урында бәрәңгене, помидорны кабат игү яки аларны бер-берсе белән чиратлаштыру үсемлекләрдә фитофтора авыруын көчәйтә.* Чәчү әйләнеше – игенчелекнең нигезе

**ФИТОФТОРОЗ** *и. гр.* Фитофтора китереп чыгара торган авыру. *Әгәр*

*бәрәңге җиренә көл, бигрәк тә каен утыны көле кертсәң, аның бүлбеләре яхшырак үсә, аларда крахмал микъдары арта, таралып пешә, үсемлекләргә фитофтороз азрак тия.* Бакчачы, яшелчәче һәм умартачы календаре

**ФИТРӘТ** *и. гар.* 1) Ике пәйгамбәр арасында пәйгамбәрсез үткән вакыт

2) Ике хөкемдар арасында хөкемдарсыз үткән вакыт

3) Ике вакыйга арасындагы вакыт

4) *дини* Ислам диненә күрә, Гайсә пәйгамбәр белән Мөхәммәд пәйгамбәр арасындагы чор

◊ **Фитрәт заманы** Торгынлык, туктап тору чоры. *Фитрәт заманында күгәреп басылып яткан сәнаигы нәфисә әбелхәят белән сугарылган иреклек һавасында җанлана, хәрәкәтләнә, аякка баса...* М.Мәһдиев

**ФИТЪРӘТ** *и. гар.* 1) Тумыштан килгән үзенчәлек. *Үзем бер җүләр вә фитърәтем җиһанга килмешәк икән.* Г.Тукай

2) Кеше аягы басмаган табигать

**ФИТЪРЫЙ** *с. гар.* Тумыштан килгән, табигый. *Никитинның фитърый таланты, минемчә, Пушкиннан ким түгел.* Г.Тукай

**ФИТЫР** *и. гар.* Рамазан ае дәвамында бирелә торган микъдары билгеле садака. *Мәхәллә дә, бөтен ихлас белән, муллалар мохтаҗлык күрмәсен дип, гошерне, фитырны, гүр садакасын, нәфел садакасын ташый гына бирәләр.* Г.Исхакый. *Байлар аңа зәкяттән, фитырдан өлеш чыгара, җиңелрәк эш булса, чакырып эшләтеп сыйлыйлар да.* Г.Ибраһимов

**ФИТЫРЛЫК** *и.* **1.** Фитырга бирергә дип әзерләнгән әйбер

**2.** *с. мәгъ.* Фитыр өчен билгеләнгән

**ФИҮ** *иярт. к.* **фью**. *Ә син фиү-фиү сызгырудан башканы белмисең, сыбызгы!* Р.Батулла

**ФИ́ШКА** *и. рус* Өстәл уеннарында очколарны, йөрешләрне санау өчен кулланыла торган фигуралар, шакмаклар, түгәрәкләр. *Хәзер, рулетканы һәр әйләндереп җибәрү алдыннан, яшел өстәл өсте төрле төстәге фишкалар белән тула башлады.* Р.Мирхәйдәров

**ФЛАГ** *и. нем.* Әләм; таяк очына беркетелгән, кабул ителгән зурлыктагы һәм төстәге, дәүләт яки оешманың эмблемасы, гербы төшерелгән тукыма кисәге. *Бу кызыл флаглар Газинурны станциядән станциягә озатып баралар.* Г.Әпсәләмов. *Шәһәрдәге бөтен йортларга бәйрәм флаглары эленә.* Ә.Еники

**ФЛА́ГМАН** *и. голл.* 1) Флот, хәрби корабльләр берләшмәсе командующие яки ул булган корабль. *I ранг флагманы В.Орлов «Сталин» миноносецында океанга чыга.* М.Мәһдиев. *Бу лайнер [«Россия» дизель-электроходы] пароходчылыкның флагманы иде.* М.Юныс

2) *күч.* Әйдәп баручы, маяк. *Түбән Кама «Нефтехим» производство берләшмәсе – Татарстан индустриясенең көчле флагманы гына түгел, бәлки үз тармагындагы Америка, Европа һәм Азия кыйтгаларындагы гигантларның да көчле көндәше.* Мирас

**ФЛАГШТОК** *и. нем.* Флаг күтәрү колгасы. *Флагшток тирәсе чәчәк клумбалары белән бизәлгән, элемтә үзәкләренең исеме, татар һәм рус телләрендә язылып, халыкны үзенә тартып тора.* Ватаным Татарстан

**ФЛАЖОК** *и. рус* 1) Сигнал бирү, бизәү һ.б. өчен кечкенә флагчык. *Флажокларын күтәрде әнә көлеп.* Ә.Исхак. *Без – флот элемтәчеләре, флажок белән сөйләшергә өйрәнәбез.* М.Мәһдиев

2) Берәр нәрсәне билгеләү өчен кулланылган кечкенә флагчык. *Флажок артында капкын буласын көт тә тор.* А.Хәсәнов

**ФЛАКОН** *и. фр.* 1) Ислемай шешәсе. *Шунда аның [Илшатның] шул ук көзгедә чагылган туалет өстәлендәге буш флаконга күзе төште. Бу бик кыйммәтле хушбуйның матур сырлы шешәсе иде.* Г.Әпсәләмов

2) Аз күләмдәге сыек әйберләрне саклау өчен, тыгыз ябыла торган кечкенә шешә. *Соңыннан врач сейфыннан пластмасса флаконга тутырылган дару алды.* Ф.Садриев. *Менә алып килгән дүрт флакон кан да бетте.* М.Мостафин

**ФЛАМАНД** *и.* Төньяк һәм Көнбатыш Бельгиядә, Франциянең Фландрия өлешендә һәм Голландиядә яшәүче, телләре герман төркеменә караган, католик динендәге халык һәм шул халыкның бер вәкиле. *Моның шулай булганын шаһитлар раслый: венгр монахы миссионер Юлиан нәкъ шул яулар заманында Монголиягә барып чыга; сәяхәтче фламанд Гильом Рубрук исә XIII йөзнең урталарында шунда барып кайта.* Р.Фәхретдинов. *Французча яхшы белә идем, ә Бельгиядә күбрәк фламанд теле кирәк булды.* Сөембикә

**ФЛАМИ́НГО** *и. лат. зоол.* Фламинголар семьялыгының бердәнбер вәкиле булган, алсу йонлы, гадәттән тыш озын муенлы, озын аяклы, гәүдәсенә карата чагыштырмача зур башлы, җылы якта яши торган кош; кызыл каз. *Фазан, фламинго, кондор яшәмәгәндер бездә, яшәгән булсалар, җырга керми калмаслар иде.* М.Мәһдиев. *Кышлыкка Каспий ярларына --- төньяктан кыр үрдәкләре, кыр казлары, Африка ярларыннан ак челәннәр, кызгылт фламинголар җыйнала.* А.Муранов

**ФЛАНГ** *и. фр.* 1) *хәрби* Сугышчан хәлдәге гаскәрнең бер ян ягы; канат, кул. *Боз өстеннән озын-озын сикереп, фрицлар сул флангка да үтә башладылар.* И.Гази. *Бурыч ачык: фланглардан үтеп, батальонның артына төшү өчен юллар капшарга, батальон штабының кайда урнашканлыгын дөрес итеп белеп кайтырга.* Ф.Хөсни

2) Кара-каршы уенда уен кырының ян яклары. *Малай минем уң флангны пешкалары белән терәтеп куйды.* Г.Афзал

**ФЛАНЕЛЬ** *и. фр.* **1.** Мамыкланып торган йомшак, җылы киҗе-мамык тукыма. *Өстендә – чиядәй кызыл фланельдән тегелгән чаңгычылар курткасы.* А.Расих. *Алтын йөгертелгән әйберне йомырка агына манчылган фланель кисәге белән яхшы чистартырга мөмкин.* Йорт эшләре

**2.** *с. мәгъ.* Шул тукымадан тегелгән. *Чәчләрен мәзәк кенә ике юка толымга үргән, шау чәчәкле фланель халат кигән.* Д.Булатова

**ФЛЕБИТ** *и. гр. мед.* Вена стеналарының эчке катламы ялкынсынуы

**ФЛЕ́ГМА** *и. гр.* 1) *мед. иск.* Лайла, какырык, эрен. *Әче торма – тәнендә флегма күп булган, шулай ук бөерләр белән интегүчеләр өчен файдалы.* Мөселман календаре

2) Чиксез битарафлык, артык дәрәҗәдәге салкын канлылык. *Күз карашындагы боздай флегма*

3) *хим.* Газ хәлендәге, сыек, бөртекле кушылмаларны өлешләп куганда калган куерык

**ФЛЕГМА́ТИК** *с. гр.* **1.** Темпераментның бер төре: артык дәрәҗәдә тыныч, ваемсыз, сүлпән. *Ул беркайчан да онытылып чыгырыннан чыкмас, үзен һәрдаим рухи тигезлектә тотар, ләкин ул сүлпән, флегматик кеше дә түгел.* А.Расих

**2.** *и. мәгъ.* Шундый темпераменттагы кеше. *Холыкларыбыз туры килмәде: --- ул – флегматик, ә мин – сангвиник.* М.Насыйбуллин. *Бередә --- шәхеснең*

*дүрт темпераменты да шактый ачык күренә: сангвиник һәм флегматик төрлечә качалар, меланхоликның буыннары бушый, холерик исә, кыдрачланып, үз хокукларын якларга җыена.* Кызыклы психология

**ФЛЕГМА́ТИКЛЫК** *и.* Флегматик темпераментка хас сыйфатлар; флегматик темпераментка ия булу

**ФЛЕГМО́НА** *и. гр. мед.* Тире астындагы йомшак тукыма эренләп ялкынсыну. *Гангрена, флегмона сәбәпле бармакны кисү – юктан гына килеп чыккан нәрсәләр түгел бит инде*. Безнең гәҗит

**ФЛЕ́ЙТА** *и. ит.* Тавыш тишекләре һәм клапаннары булган туры озын көпшә формасындагы югары регистрлы тынлы музыка коралы. *Флейта һәм кларнетларга яңадан җан керде. Флейталарның яңгыравык авазлары гел югарыга омтылды.* Ш.Хөсәенов. *Симфонияләрдә барабаннар һәм литавралар тантана итә, скрипкалардан үзәк өзгеч моң һәм сагыш агыла, флейталар, елап, сулкылдап-сулкылдап куя.* Ә.Рәшит

**ФЛЕ́ЙТАЧЫ** *и.* Флейтада уйнаучы. *Шул елларда Н.Җиһанов, Ф.Яруллин һәм флейтачы Батыршин, үзенчәлекле трио оештырып, театр спектакльләрендә уңышлы гына чыгышлар ясый иделәр.* К.Таһиров

**ФЛЕ́КСИЯ** *и. лат. лингв.* 1) *иск.* Төрле грамматик формаларда сүзләрнең тамырлары һәм кушымчалары үзгәрү сәләте

2) Сүзнең төрләнгән вакытта грамматик мәгънәсен белдерә торган кисәге. *Гомуми тел гыйлемендә --- сүзнең иң соңында килә торганнарын [кушымчаларны] флексия дип аерып атап йөртәләр.* Татар грамматикасы

**ФЛЕКТИВ** *с. лингв.* Сүзләрнең тамырларын һәм кушымчаларын үзгәртү юлы белән яңа грамматик төшенчәләр ясый торган. *Флектив телләрдән аермалы буларак, тамыр морфемалар бер генә морфлы булалар.* Татар грамматикасы

**ФЛЕ́ШКА** *и. рус сөйл. к.* **флеш карта**. *Алар флешкаларны кулланылыштан бөтенләй кысрыклап чыгармас микән?* Д.Сәфәров

**ФЛЕШ КА́РТА** *и. информ.* Цифрлы мәгълүматны саклау өчен файдаланыла торган кечкенә электрон җайланма. *Кайбыч эшмәкәрләренең барысына да бизнес-проект турындагы буклет, блокнот, ручка, презентацияле флеш карта салынган пакетлар бирделәр.* Кайбыч таңнары

**ФЛЕШМОБ** *и. ингл.* Бер төркем кешенең алдан билгеләнгән урында һәм вакытта кинәт пәйда булып, сөйләшеп куелган сценарий буенча билгеле хәрәкәтләр ясагач та таралышудан гыйбарәт акция. *Якшәмбедә Мәскәүдә «Бабайны пенсиягә озатыйк» дигән флешмоб үткәрелде.* С.Кутушев. *Космонавтларны мәктәп укучылары флешмоб белән каршы алды, аларга үзләре ясаган рәсем күргәзмәсен күрсәттеләр.* Казан утлары

**ФЛЁР** *и. нем.* 1) Үтәкүренмәле юка ефәк тукыма. *Ак флёрның читләре челтәрләп каелган*. Ф.Әмирхан

2) *күч.* Серле япма. *Теге якта нарат урман өстенә кыеклап кына, нечкә пәрдә кебек сыек кына ак болыттан флёр ябылган иде.* Г.Исхакый

**ФЛИБУСТЬЕР** *и. голл.* Диңгез юлбасары, пират. *Пароход палубасына эләккән һәр пассажир үзен җил-давыл белән көрәшеп океан гизәргә, кеше аягы тимәгән яңа атаулар ачарга чыккан диңгез флибустьерлары итеп сизә иде.* М.Юныс

**ФЛИ́ГЕЛЬ** *и. нем.* Йортка терәп салынган ян корылма яки ишегалдындагы аерым кечерәк йорт. *Тәмәке көйрәтү белән, алар икесе дә полк штабы урнашкан ике катлы флигельгә таба әйләнеп утырдылар.* К.Нәҗми. *Шакир абзыйлар үзләре капканың сул ягындагы бер катлы җыйнак кына флигельдә яшиләр.* А.Расих

**ФЛИ́ГЕЛЬ-АДЪЮТАНТ** *и. нем. тар.* Патшаны саклап, аны озатып йөрүче офицер; армия командующиеның йомышларын үтәүче офицер. *Мондый канечкеч флигель-адъютантлар кайда тудылар икән?* К.Нәҗми

**ФЛИРТ** *и. ингл.* Гыйшык уены, гыйшык-мыйшык. *Әхлак ягыннан тел-теш тидерерлек булмаса да, хатын-кыз белән аралашырга ярата, җиңелчә флирттан да качмый.* И.Нуруллин. *Рина белән сәйран чигүен дә, гади бер флирт, гыйшык сату дип түгел, алман рухын үзләштерү дип танырга мөмкин.* Т.Әйди

**ФЛИС** *и. ингл.* **1.** Җылы кием тегү өчен полиэстердан эшләнгән синтетик трикотаж тукыма

**2.** Шул тукымадан тегелгән. *Шуннан соң эшкәртелгән чималдан флис киемнәр, пледлар, үсентеләр өчен савытлар, сумкалар кебек кирәкле әйберләр ясала.* Шәһри Чаллы

**ФЛОКС** *и. гр. бот.* Күкчәчәкләр семьялыгыннан декоратив максат белән үстерелә торган, хуш исле чәчәкләре эре-эре төркемнәргә оешкан күпьеллык үлән үсемлек. *Купшы флокслардан бөтен ишегалдына тәмле хуш ис таралган.* Т.Әйди

**ФЛОМА́СТЕР** *и. ингл.* Көпшәк материалга махсус буяу сеңдерелеп эшләнгән үзәге булган язу-сызу әсбабы. *[Чакыру кәгазьләрен] Казанда типографиядә басылганнарын төргәге белән юнәткән идек, авыл исемен, сәгатен генә төсле фломастер белән тутырып ябыштырабыз.* М.Мәһдиев. *Зуфирәнең кулы астында фломастер белән сызган сызыклар җанланды, хәрәкәткә килде.* М.Маликова

**ФЛО́ППИ ДИСК** *и. ингл. информ.* Компьютердагы материалны тышкы хәтердә саклау өчен кулланыла торган магнитлы диск; дискета

**ФЛО́РА** *и. лат.* 1) Борынгы Рим мифологиясендә яз һәм чәчәкләр алиһәсе

2) Аерым бер чор яки төбәккә караган үсемлекләр. *Ләкин бу чорның үзенең дә фаунасы һәм флорасы барлыкка килгән.* А.Фәтхуллин. *Бу чордагы флора һәм фауна утырма файдалы казылмаларга башлангыч бирә.* Кызыклы география

**ФЛОРИ́СТИКА** *и. лат. махс.* 1) Җир шарындагы яки аның аерым өлкәләрендәге үсемлекләрне өйрәнү, бу үсемлекләрнең төрләрен системалаштыру белән шөгыльләнә торган ботаника фәненең бер тармагы

2) Табигый материаллардан, киптерелгән яки тере үсемлекләрдән (чәчәк, җимеш, чикләвек, яфрак, мүк һ.б.дан) нәфис әсәрләр ясау сәнгате, интерьерны чәчәк композицияләре белән бизәү осталыгы. *Быелгы сменага планнар зурдан: остаханәләр исемлегенә сәхнә теле, массаж, флористика юнәлешләрен дә өстәргә уйлыйм.* Кызыл таң. *Студент вакытта флористика белән мавыгып, махсус курслар тәмамлый, --- унышар сәгать буе бер өзелмичә картиналар тудырган чаклары була.* Мәдәни җомга

**ФЛОТ** *и. фр.* 1) Илнең, аерым диңгез, елга бассейннарының хәрби яки сәүдә суднолары җыелмасы. *Бәрәскә авылыннан флотта хезмәт итеп кайткан диңгезче Гарифулла Хәмидуллин берүзе 200 баш сыерны котырып аккан елганың бер ягыннан икенче ягына алып чыга.* Г.Ахунов. *Бөекбритания башка илләр белән тышкы элемтәне диңгез флоты ярдәмендә алып бара.* Чит илләрнең экономик географиясе

2) Хәрби диңгез көчләренең (корабльләр, су асты көймәләре, диңгез авиациясе һ.б.ларның) зур берләшмәсе. *Тын океан флоты. Кара диңгез флоты*

**ФЛОТА́ЦИЯ** *и. фр. махс.* Файдалы казылмаларны магнитлы суда баету ысулы. *Магнитланган суны файдаланып, бакыр, кургаш һәм фосфор рудалары флотациясенең файдалы эш коэффициентын егерме проценттан илле процентка кадәр күтәрү мөмкинлеге туа.* Могҗизалар энциклопедиясе

**ФЛОТИ́ЛИЯ** *и. фр.* 1) Билгеле бер елга, күл, диңгезгә караган хәрби суднолар җыелмасы. *Азов диңгезе флотилиясенә --- безнең гаскәрләрне акларның диңгез флотилиясе һөҗүменнән саклауны тәэмин итәргә кушылды.* Г.Бәширов. *Амур флотилиясенең базасына мине автобус илтеп куйды.* М.Мәһдиев. *Идел флотилиясе*

2) Махсус суднолар отряды. *Онеганың балык тоту белән махсус шөгыльләнә торган үз флотилиясе бар.* А.Муранов

**ФЛОТЧЫ** *и.* Флотта хезмәт итүче. *Әй шат хәзер балалар! Морякның үзе белән, Кызыл флотчы белән таныш булдылар алар.* С.Михалков. *Кызыл флотчы абый Бүген бездә ял итә, Иртәгә хезмәтенә – Ерак диңгезгә китә.* Ә.Бикчәнтәева

**ФЛЮ́ГЕР** *и. нем.* 1) Төз, туры колгага беркетелгән, үз күчәрендә әйләнеп, җилнең юнәлешен, тизлеген билгели торган җайланма. *Әтәч сынын, сурәтен капка, өй башларына беркеткәннәр, --- җил юнәлешен күрсәтүче флюгер сыйфатында кулланганнар.* Г.Гыйльманов. *Җирле билгеләр буенча һава торышын алдан әйтү өчен, барометр күрсәткечләрен дә, флюгер һәм термометр күрсәткечләрен дә искә алу мөһим.* Бакчачы, яшелчәче һәм умартачы календаре

2) *тар.* Атлы сугышчы сөңгесе очындагы кечкенә флаг

3) *күч.* Аумакай, икейөзле кеше. *Хәзерге татар совет байлары күңелен май басты, татар милли зыялыларының күпчелеге калай әтәчкә – флюгерга әйләнде, яисә яфрак астына башын тыгып ятуны сайлады.* Ә.Кәримуллин. *Кичә кочаклаганны – әйдә дөмбәсләргә, кичә мактаганны – әйдә хурларга!.. Чып-чын флюгерлар без, колгага эленгән уенчыклар.* Казан утлары

**ФЛЮОРОГРА́ФИЯ** *и. лат.* 1) Рентген нурлары ярдәмендә әгъзаларны фотосурәткә алып тикшерү методы. *Флюорография нәтиҗәләре*

2) Шундый аппарат урнаштырылган бүлмә яки йорт. *Авыруны флюорографиягә җибәрү*

**ФЛЮС** I *и. нем.* Теш бакасы, теш төбе үлекләп, яңак шешү. *Яңак сөяге өстендә шешләр – флюс барлыкка килсә, ул кешегә бака булган, бака кергән, бака тигән, диләр.* Г.Гыйльманов

**ФЛЮС** II *и. нем. тех.* 1) Металлургиядә: тиешле үзлеккә ия булган шлак алу (катнашманың эрүен тизләтү) өчен шихтага кушыла торган матдә

2) Металларны эретеп ябыштырганда оксидларны эретә торган химикат

3) Балчык һәм фарфор әйберләр җитештерүдә: яндырганда кызәнәкләрне томалау өчен салына торган тиз эрүчән матдә

**ФЛЮСЛАШТЫРУ** *ф. махс.* Флюс кушу

**ФЛЯ́ГА** *и. нем.* 1) Иңбашына асып яки бил каешына элеп, юлга үзең белән су алу өчен җайлаштырылган яссы металл савыт, шешә. *Үз-үзен белештермичә, кызып эшли-эшли дә, флягасын күтәреп, колт-колт су йота.* И.Гази. *«Су юк бит», – диде һәм, сүзенраслар өчен, флягасын ачып, җиргә аударып күрсәтте.* Т.Әйди

2) Сыеклык салып йөртә торган, янякларында тоткасы булган күп сыйдырышлы савыт. *Арбаны яр кырыена куеп, яр астыннан суны яртышар чиләкләп ташып, фляганы тутырганчы гына да дөнья хәтле вакыт үткән булып чыкты.* В.Нуруллин. --- *ачык урыс капкалардан хатын-кызларның чиләк, фляга күтәреп йөргәннәре күренә.* М.Мәһдиев

**ФЛЯ́ЖКА** *и. рус к.* **фляга** (*1 мәгъ.*). *Шулай дигән дә бу, тиз генә янындагы калай фляжкасын алып тегеңә сузган.* Н.Исәнбәт

**ФО́БИЯ** *и. лат. мед.* Ниндидер предметлардан, хәрәкәт, ситуацияләрдән котылгысыз курку авыруы. *Ә һәр төрле фобия ул – авыру галәмәте. Кемдер уттан курка, әмма аңа карап утсыз яшәп булмый.* Ф.Бәйрәмова

**ФОЙЕ** *и. фр.* Кино, театр һ.б.ш.да тамаша алдыннан яки тәнәфес вакытында тамашачыларның туплану, ял итү урыны. *Фойега җыелган тамашачыларны сеанс башланыр алдыннан залга кертәләр дә, халык урнашкач, билет тикшерә башлыйлар.* А.Расих. *Алар театрны Кабан ярына утыртып кына калмаганнар, гүя күлнең үзен театр эченә керткәннәр, фойедан күренеп тора ул.* Р.Мостафин

**ФОК** *и. голл. диң.* Суднода алгы мачтаның аскы туры җилкәне яки бер мачталы суднода өчпочмаклы җилкән

**ФОКАЛЬ** *с.* Фокуска (I) караган, фокуска мөнәсәбәтле. *Әйбер җитәрлек кадәр ерак торганда, фотопластинка объективның фокаль яссылыгына якын китерелә.* Физика курсы

**ФОК-МА́ЧТА** *и. нем.-рус махс.* Судноның алгы өлешендәге мачтасы. *Мәнә фок-мачтадагы мичкәдән күзәтүче матросның «фонтан!» дип кычкырганы ишетелә.* Кызыклар дөньясында

**ФОКСТЕРЬЕР** *и. ингл.* Ау этләренең кечкенә гәүдәле токымы

**ФОКСТРОТ** *и. ингл.* Дүрт өлешкә бүленгән тактлы бию һәм шул биюнең көе. *Иске патефон гыжылдавык тавыш белән фокстрот көйли башлады.* Н.Фәттах. *Серләр килешер сыман иде, фокстрот биегәндә, ул инде шушы кызны озатып куярга да тәгаен карар иткән иде.* Т.Әйди

**ФО́КУС** I *и. лат. физ.* 1) Кайтарылган яки сынган нурларның кисешү ноктасы. *Телескопта окулярны аның алгы фокусы объективның арткы фокусы белән бергә туры килерлек итеп урнаштыралар.* Физика курсы. *Аның [күзнең] яктылык нурларын сындыручы һәм аларны күзнең арткы стенасының эчке өслегендә фокуска җыючы махсус җайланмалары бар ---.* Кызыклы физиология

2) Фоторәсемгә төшергәндә фотоаппарат аша сурәтнең иң яхшы күренү ноктасы. *Карточкага дөрес төшермәгәннәр боларны... Фокуска кесәләрен алырга кирәк иде, чөнки хикмәт фәстә дә, мыекта да, генералның түшендәге орденда да түгел, ә кесәдә, акчада.* М.Маликова. *Фотографиядә фокуска дөрес төбәү бик әһәмиятле: әгәр алгы план аермачык килеп чыкса, ә ераграк торган нәрсәләр «фокуста» булмасалар, – пространствоны «тирән» итеп күрсәтү өчен шул җитә.* Кызыклы физика

3) *мед.* Ялкынсыну процессының төп учагы

4) *лингв.* Кеше сөйләгәндә өрелеп чыккан һаваның үз юлындагы стеналарга ышкылудан аваз ясый торган тарайган урын. *Өрелмәле тартыклар бер фокуслы һәм ике фокуслы булалар. Бер фокуслыларны әйткәндә, һава агымы бер генә фокус аша үтә, ә ике фокуслылар берьюлы ике урыннан һава өрелеп*

*чыгу нәтиҗәсендә ясалалар.* Татар грамматикасы

5) *күч.* Вакыйгаларның үзәге, эшхәрәкәтнең, мәсьәләнең уртасы. *Бәхетле Рафаэль йөзләгән кешенең баш миен, йөрәген, карашын үзенең калку зәңгәр күзләренә җыйды да бер фокуска туплады.* М.Мәһдиев. *Анда күтәрелгән мәсьәләләрне бер фокуска – иң элек «Инкыйраз»га һәм әдипнең башка әсәрләренә барып тоташтыра.* Сөембикә

**ФО́КУС** II *и. нем.* 1) Ялгыш күрүгә нигезләнгән, кул һәм бармакларның тиз хәрәкәте нәтиҗәсендә оста башкарылган трюк, алдау. *Борынгы Кытайда күз буу, фокус сәнгатенең үсеп китүендә мисырлыларның йогынтысы көчле булган.* Н.Фәттах. *Рәшат исә, әтисе кебек, уен-көлке яратучан, сурәт ясарга, әллә нинди хикмәтле фокуслар күрсәтергә, төрле уенчыклар уйлап чыгарырга сәләтле, кирәгендә коры да, нык та була белә.* А.Расих

2) Сер, әкәмәт, нәрсәнең булса да гаҗәп ягы. --- *«Приватизация» ясау юлы белән аның [КамАЗның] мөлкәтен үзләштерү фокусы иде бу, әлбәттә...* З.Мифтахов

3) Көйсезлек, холыксызлык, кирелек. *– Кая качасың?! Тукта! – диде Котбетдин хәйран калып: – Кем кемне тота, нинди фокус бу?! Ах, өйрәнәсе калган боксны...* А.Алиш

◊ **Фокус чыгару** Көтелмәгән кире эш эшләү

**ФО́КУСЧЫ** *и.* Фокус күрсәтүче артист. *Кытайга Мисырдан күз буучылар, фокусчылар килә торган булган.* Н.Фәттах. *Бер фокусчы витрина яныннан үткәндә кырыкка якын предметны күрә һәм аннары тасвир итә алган.* Кызыклы психология

**ФО́КУСЧЫЛЫК** *и.* 1) Фокус күрсәтү һөнәре

2) *күч.* Ялганлау, тартынмыйча алдау

**ФОЛИАНТ** *и. нем.* Зур форматлы, калын, зиннәтле китап. *Миңа шуның өчен дә татар күчермәләре арасында алтынлап язылып, миниатюралар белән бизәлеп, хәтфә тышлары көмеш белән зиннәтләнгән купшы фолиантлар бөтенләй юк дип әйтерлек.* М.Госманов. *Зур китапханәләрдә битләре бозау тиресеннән ясалган борынгы фолиантлар да бар.* М.Юныс

**ФОЛК** *и. ингл.* Музыканың кайбер халыкчан жанрларының гомуми атамасы. *Без уйнаган музыканың форматы да гадәти түгел – бу глэм, рэп, фолк кебек стильләр катнашмасы.* Идел

**ФОЛК ТӨРКЕМ** *и.* Халык көйләрен эстрада рухында эшкәртеп башкара торган төркем. *«Бәрмәнчек» керәшен дәүләт фольклор ансамбле танылган керәшен җырларын --- фолк төркеме белән берлектә, яңача эшкәртеп тәкъдим итәргә җыена.* Туганайлар

**ФОЛЬГА** *и. лат.* Төсле металлардан яки буяу кушып ясалган юка металл кәгазь. *Кызның башында шул ук фольгадан ясалган көмеш таҗ балкый, --- таҗына алтынсу төстәге икенче фольга белән «1951 ел» дигән сүзләр беркетелгән.* Р.Мирхәйдәров. *Конденсаторның йөзлекләре кургаш һәм аккургаштан яки алюминийдан эшләнгән фольгадан ясала.* Физика курсы

**ФОЛЬКЛОР** *и. ингл.* Халык иҗаты, халык сәнгате. *Ләкин борынгы җырларда, фольклор материалларында традицион -дыйн/-дин формасын әле дә очратырга мөмкин.* Л.Җәләй. *«Җырлыйк Түмән көйләренә» дип исемләнгән язмасы укучыларыбызны Себер татарларының гаять тә үзенчәлекле җыр фольклоры дөньясына чакыра.* Казан утлары

**ФОЛЬКЛОРИ́СТИК** *с.* Фольклористикага караган, фольклористикага мөнәсәбәтле. *Инде хәзер башкорт этнонимына дәхелле тарихи, этнографик һәм фольклористик мәгълүматлар вә закончалыклар илә танышып карыйк.* Мирас

**ФОЛЬКЛОРИ́СТИКА** *и. рус* Халык авыз иҗаты турындагы фән. *Мондый хезмәтнең татар фольклористикасында һәм китап басу тарихында әлегәчә булганы юк иде, бу – милли мәдәниятебезнең мөһим казанышы дип бәяләнергә тиеш.* Татар халык әкиятләре

**ФОЛЬКЛОРЛАШУ** *ф.* Фольклорга, халык авыз иҗатына әверелү. *Фольклорлашу – халыклашкан җырлар өчен хас күренеш.* К.Миңнуллин

**Фольклорлаша бару** Торган саен ныграк фольклорлашу

**Фольклорлашып китү** Күпмедер вакыттан соң фольклорлашу. *Ягъни алар [Ә.Ясәви хикмәтләре] берникадәр фольклорлашып киткәннәр, телдән – телгә, кульязмадан кульязмаларга күчерелгәндә шомартыла барганнар.* Ф.Яхин. *Шәкерт дәфтәрләре безгә шулай ук кайсы шагыйрьләребезнең нинди әсәрләре халык арасында киң таралуын, кайберләренең бөтенләй фольклорлашып китүен ачыклау өчен дә бай мәгълүмат бирә.* М.Госманов

**ФОЛЬКЛОРЧЫ** *и.* Халык авыз иҗатын туплаучы, фольклор әсәрләрен җыючы, аларны өйрәнүче кеше. *Аның бу эшен соңыннан рус фольклорчысы һәм тарихчысы А.Ф. Гильфердинг дәвам итә.* А.Муранов. *Аның [Афзал Таһировның] язучы һәм фольклорчы Фазыл Туйкә белән берлектә «Тирмән» исемле кульязма сатирик журнал чыгаруы --- билгеле.* Мәдәни җомга

**ФОЛЬКЛОРЧЫЛ** *с.* Фольклорга әйләнерлек, фольклор әсәре булырлык. *С.Күкләшев хрестоматиясенең әдәбият бүлеге тулысынча «Буз егет»тән башланган яңа поэтик принципларга нигезләнгән фольклорчыл хикәятләрдән гыйбарәт.* Ә.Дусайлы

**ФОЛЬКСВА́ГЕН** *и. нем.* Германиянең шул исемдәге компаниясе чыгарган автомобиль маркасы. *Үзенең «Мерседес»ы, «Пежо»сы, «Волга»сы, «Фольксваген»ы булган чит ил туристлары бары тик тарантаслы атка гына утырып йөриләр.* М.Мәһдиев

**ФОН** I *и. лат.* 1) Бизәк, язу һ.б.ш. урнашкан төп төс; җирлек. *Алар шулай оста урнаштырылганнар ки, орнаментлы бизәкле фон гүя ташларның балкуын дәвам итә.* Сөембикә

2) Арткы пландагы күренеш. *Ә көзен генә була торган саф зәңгәр күк фонындагы усак катнаш каен урманын күрегез әле.* Г.Гобәй. *Якты фондагы әйберләр ачыграк күренә, шуңа күрә алар күк фонында тау яисә урман фонындагыга караганда якынрак кебек тоела.* Кызыклы психология

3) *күч.* Гомуми хәл, шартлар, тирәюнь, мохит. *Шәхси мәнфәгатьләре, җөмләдән Мәскәүдән килә торган вак-төяк бүләкләр хакына сепаратлык юлына баскан, үз иленең, туган халкының интересларын саткан көтү-көтү бәкләр, мирзалар фонында иленә һәм иманына тугрылыклы хәлдә калган Сөембикә образы аерата калку булып гәүдәләнә.* М.Госманов. *Әйтик, мондый характердагы каршылык --- «Тартышу» драмасында (1908) инде инкыйраз көчләренең гамәле, сыйнфый каршылыклар формасын алып, шактый җитди сәяси фон тудыра.* Мирас

**ФОН** II *и. гр.* 1) *махс.* Тавыш көчен үлчәү берәмлеге

2) *лингв.* Фонеманың конкрет гәүдәләнеше, сөйләмнең билгеле акустик үзлекләргә ия иң кечкенә кисәге

**ФОН** III *и. нем.* Немец фамилиясе алдыннан куела торган, дворян нәселеннән булуны күрсәткән кисәкчә. *Тирә-як крестьяннарның «тыңламас алпавыты» дип йөрткән кешесе, Фон Глен дигән немец булып, ул үз җирен крестьяннардан эшләттерә.* Ә.Фәйзи

**ФОНАРЬ** *и. гр.* 1) Эченә яктылык чыганагы урнаштырылган яки механик рәвештә хәрәкәткә китереп яктылык бирә торган җайланма. *Авыл кешеләренең көчле буранда кулланыла торган гадәте буенча, манара тәрәзәсенә якты фонарь элеп куюлары, шул ук вакытта балалары белән хатынының әтиләрен ничек борчылып көтүләре ярыйсы ук тәфсилләп, шуның өстенә шактый ук кызганыч итеп язылган иде.* Г.Бәширов. *Кесә фонаре, бер янып, бер сүнеп, кемгәдер сигнал бирә башлады.* Р.Батулла

2) Өй түбәсенә ясалган тәрәзә

3) *күч.* Үзеннән яктылык чыгара торган тереклекияләре. *Диңгез упкыннары һәм куе тропик урманнар – тере фонарьларның яраткан урыны ---.* Кызыклы физиология

4) *күч.* Кан савып күгәргән урын. *Нәрсә, күз төбеңдәге бер фонарь гына җитмәгәнмени? Тагын бирәү кирәкме?* А.Тимергалин

◊ **Фонарь кабызу** Күздән ут чыкканчы сугу, күгәрткәнче сугу. *Күз төбеңә фонарь кабызып йөр әле, карак дуңгыз!* Н.Гыйматдинова. **Фонарь кую** Күгәрткәнче сугу, бәрү, бәрелү. *Менә маңгайга нинди фонарь куйдым, күрәсеңме, тип-тигез урында ташка абындым бит.* З.Фәтхетдинов. **Фонарь утырту** *к.* **фонарь кую**

**ФОНАРЬЧЫ** *и. иск.* Урамдагы фонарьларны кабызучы-сүндерүче. *Арага фонарьчы Хәйбүш кызы Мәрфуга килеп кысылды.* К.Нәҗми

**ФОНАЦИОН** *с. лингв.* Фонациягә бәйле. *[б] авазын әйткәндә зурайган резонатор иреннәр шаулавы һәм йоткылык тавышыннан түбәнрәк тоннарны зурайта, һәм резонатор аша чыгучы фонацион һава тагын да түбәнрәк тонда яңгыраш бирә.* Фән һәм тел

**ФОНА́ЦИЯ** *и. фр. лингв.* Авазларны әйтү процессы, аларның яңгырашы

**ФОНД** *и. лат.* 1) Матди средстволар туплап, шуларны төрле җитди социаль максатларга юнәлтә торган иҗтимагый оешма; вәкыф. *Айсылу, Мәрьямгә әнә шул фондтан ярдәм итәргә кирәк булыр, дигән уйга килде.* Г.Бәширов. *--- солдат балаларына ярдәм фонды бар аларның.* В.Нуруллин

2) Бюджеттан тәэмин ителә яки бюджетка бәйсез, дәүләт мәнфәгатьләренә хезмәт итә торган дәүләт оешмасы. *Пенсия фонды*

3) Билгеле максатларга дип тупланган акча, запас, резерв. *Шуның өстенә тагын оборона фонды өчен утыз гектар арттырып та чәчәбез.* Р.Ишморат

4) Табыш бирә торган кыйммәтле кәгазьләр. *Фонд базары. Фонд биржасы*

5) *күч.* Тарих, культура һ.б.ш.ның әһәмиятле казанышлары, рухи байлык. *М.Гафуриның иҗаты татар совет әдәбияты фондына кыйммәтле бер җәүһәр булып кереп калды.* М.Җәлил

**ФОНЕ́МА** *и. гр. лингв.* Сүзләрне һәм аларның грамматик кисәкләрен төзи һәм мәгънәви яктан аера торган иң кечкенә сөйләм кисәге, аваз. *Анда фонемаларны аерып алу критерийлары бирелә, шулар нигезендә татар теленең фонемалар составы ачыклана.* Татар грамматикасы. *Сөйләшергә өйрәнү өчен, бала авазлар ташкыныннан әһәмиятле билгеләрне үзләштерергә, ягъни фонемаларны аера белергә өйрәнергә тиеш.* Кызыклы физиология

**ФОНЕМА́ТИК** *с. лингв.* Фонемалардан торган. *Сөйләм процессында морфемалар төрле фонетик һәм морфемик чолганышта калалар, нәтиҗәдә, янәшә торучы морфемаларның фонематик составына бәйле рәвештә, фонетик үзгәрешләр, чиратлашулар барлыкка килә.* Татар грамматикасы. *Японнарның язма сөйләме иероглифлардан һәм сүзләрне фонематик ысул белән бирүдән гыйбарәт.* Кызыклы физиология

**ФОНЕНДОСКОП** *и. гр. мед.* Йөрәк һәм үпкә эшчәнлеген тыңлау өчен тавыш көчәйткечле җайланма. *– Юраныгызны ачыгыз, – диде профессор авыруга һәм фонендоскобын колагына җайлый башлады.* Г.Әпсәләмов. *Врач шулай сөйләнә-сөйләнә халат кесәсеннән фонендоскобын алды да Фәләхнең күкрәгенә куеп, тыңлап-тыңлап карады.* В.Нуруллин

**ФОНЕ́ТИК** *с. лингв.* Фонетикага мөнәсәбәтле, фонетикага нигезләнгән. *Татар теленең фонетик системасын өйрәнүгә Ф.Г. Исхаковның хезмәтләре зур өлеш кертә.* Татар грамматикасы

**ФОНЕ́ТИКА** *и. гр. лингв.* 1) Тел гыйлемендә авазлар яңгырашын өйрәнә торган бүлек. *Фонетика – тел белеменең бер бүлеге, ул авазларны, аларның кушылмаларын, аваз үзгәрешләрен өйрәнә.* Татар грамматикасы

2) Аерым телләрнең авазлар составы. *Татар фонетикасы буенча иң беренче фәнни мәгълүматлар К.Насыйриның «Кыскача татар грамматикасы»нда күренә.* Татар грамматикасы

**ФОНЕ́ТИКАЧЫ** *и.* Фонетика белән шөгыльләнүче галим. *Күрәсез, безнең кайбер фонетикачылар, мишәрләр «й» язсын, казанлылар «җ» язсын, һәркем ирекле булсын, кебек фикердә.* Г.Алпаров

**ФОНЕТИСТ** *и. рус к.* **фонетикачы**. *Аның [Ү.Ш. Байчураның] «Татар теленең аваз төзелеше» исемле монографиясе, тел белгечләре фикеренчә, фонетистлар таяна алырлык, чын мәгънәсендә фәнни чыганак булып тора.* Татар грамматикасы

**ФОНОГРА́ММА** *и. гр.* Авазлар язмасы (валик, пластинка, плёнка һ.б.ларда). *Аннары, сискәндерерлек итеп, кинәт кенә җырлап җибәрде, әйтерсең фонограмма уйната башлады.* Р.Мирхәйдәров

**ФОНО́ГРАФ** *и. гр.* Авазларны механик ысул белән яздыру һәм кабатлау өчен беренче җайланма. *Бу көйләр [татар халык көйләре] фонографка язылып алындылар.* К.Миңнуллин. *Гаврилов керәшен җырчылары башкаруында фоновадикларга яздырылган төрле көйләрне фонограф аша яңгыраттыра.* Н.Максимов

**ФОНОГРА́ФИК** *с.* Фонографта яздырылган. *Әлеге фонографик язмалар 1919 елда В.Банг һәм В.Шульц тарафыннан рус транскрипциясендә бастырып чыгарылалар.* Д.Рамазанова

**ФОНОЛО́ГИК** *с. гр. лингв.* Фонологиягә бәйле. *Кайбер телләрдә сузыкларның озынлыгы фонологик роль башкара, ягъни озын һәм кыска сузыклар сүзләрнең мәгънәләрен аера алалар.* Татар грамматикасы

**ФОНОЛО́ГИЯ** *и. гр. лингв.* Тел белеменең авазлар системасын һәм аларны функцияләре ягыннан өйрәнә торган тармагы. *Ул әлеге шул фонология фәненә керешме, аның кыскача сөземтәсеме буларак кабул ителә.* И.Низамов

**ФОНОСКОП** *и. гр.* Авазларның яңгырау үзенчәлекләрен, тел, ирен, йөз, авыз куышлыгы мускулларының хәрәкәтләрен өйрәнү җайланмасы

**ФОНОТЕ́КА** *и. гр.* Фонограммалар җыелмасы. *Г.Ибраһимов исемендәге*

*ТӘһСИнең фәнни архивы фонотекасында М.Нигъмәтҗанов тарафыннан теркәлгән магнитофон тасмасындагы «Хушаваз» язмасы саклана.* Г.Макаров

**ФОНТАН** *и. лат.* 1) Табигый җир асты басымы астында өскә атылып чыккан сыеклык яки газ. *Татарстанда, Бизмән тауда беренче нефть фонтаны бәрде.* А.Әхмәт. *Вулкан кратерыннан, колак тондыргыч улау тавышлары чыгарып, ап-ак булып кызган гаять зур утлы лава фонтаны бәрә башлый.* Могҗизалар энциклопедиясе

2) Чишмә, су чыганагы. *Шуңар каклы йөгер, фонтанга бар, алып чишмә суын түк, сип тә уйна.* Г.Тукай. *Ындыр табагы сыман такыр җиргә фонтан суы агызып, шугалак ясыйлар.* К.Нәҗми

3) Зур басым белән суны өскә, югарыга аттыра торган декоратив корылма. *Күңел түрендәге бөтен борчуларны әнә шул фонтан суында эретеп, бөтен уйлар дөньясына бакча һавасын кертеп җилләтәсе дә... кайгысыз булып каласы иде.* Г.Бәширов. *Шәһәр, аның таш урамнары, көне-төне аллы-кызыллы су атып утырган фонтаннары, кинотеатрлары --- кызның төрле якка ташланырга әзер күңелен бер юнәлешкәрәк алып киттеләр.* А.Гыйләҗев

4) *күч.* Зур көч белән, күп булып, югарыга бөркелеп күтәрелгән әйбер. *Җирдән күтәрелгән төтеннәр соры болытларга тоташып, домналарның моржалары яңгырлы төтен атып торган болыт фонтаннарына охшыйлар.* Һ.Такташ. *Дулкыннар бер мизгелгә җыерылып калгандай булды да, аннары югары калкып, ухылдап чәбәләнеп куйды, фонтаннар чәчеп җибәрде.* Кызыклы география

**ФОНТАНЛАНУ** *ф.* 1) *кайт. юн. к.* **фонтанлау**

2) *күч.* Көче, гайрәте ташып тору. *Яшь чагында көч күп була, Һаман фонтанланасың, Ә соңыннан нәкъ шушылай Качалкага каласың.* Х.Камалов

**ФОНТАНЛА́У** *ф.* Фонтан булып ату, өскә ургылу. *Минем исә үз режимым: әйткәнемчә, нефть коесын гел фонтанлап кына эшләтә торган режимны табасым килә иде.* Р.Төхфәтуллин

**ФОНТАНЛЫ** *с.* Фонтаны булган, фонтан белән бизәлгән. *Фонтанлы бассейннар белән ул бөтен бер кварталны биләп тора.* С.Сөләйманова

**ФО́РА** *и. ит.* 1) Көчле, тәҗрибәле уенчының көчсез көндәшенә уен башында (бильярд, шахмат, шашка һ.б. уеннарда өстәмә очколар, йөрешләр, фигуралар һ.б. белән) биргән ташламасы. *Башка атлар сызыктан дәррәү кузгалып китсә дә, Хәмидулла йөгәнне кискен каерып тотты, Акъялны урыныннан кузгатмады. – Мин сезгә юри фора бирәм!* В.Имамов

2) *күч.* Гомумән, берәүнең башкасы алдында нинди дә булса яктан өстенлеге. *Татарларның ике телгә ия булуы – руслар алдында фора һәм өстенлек.* Сәхнә

**ФО́РВАРД** *и. ингл. спорт* Футбол, хоккей һ.б. уеннарда һөҗүм итү линиясендә уйнаучы, һөҗүмче

**ФОРД** *и. инг.* Җиңел автомобиль эшләп чыгара торган транснациональ компания һәм анда җитештерелгән шундый маркадагы җиңел автомобиль. *– Сез саф татарча шундый әйбәт сөйләшәсез ки, әйтерсең лә шәһре Казанда яшәгәнсез, – дидем мин туган телемдә Форд автомобиле рулендә утырган әңгәмәдәшемә.* М.Мәхмүтов. *«Дженерал Моторс» концерны, Форд һәм Крайслер компанияләре – автомобиль промышленностенда, «Дженерал Электрик» компаниясе электротехника промышленностенда хакимлек итәләр.* Чит илләрнең экономик географиясе

**ФОРДЗОН** *и. фр.* 20 ат көченә тәңгәл егәрлекле, өсте ачык, тырнаклы тәгәрмәчле беренче тракторларның бер моделе. *Фордзонның артына тагылган ике төрәнле сабан җир телемли башлады.* А.Таһиров

**ФОРЕ́ЙТОР** *и. нем. тар.* Очлап җигелгән атларның иң алдагысына атланып баручы ат тотучы

**ФОРЕЛЬ** *и. нем.* Сөләйман балыклар семьялыгыннан төче сулыкларда яши торган, кызыл һәм кара таплы, көмеш төсендәге ялтыравыклы тәңкәле балык; керкә, багры. *Үзе ашханәгә барып, лимон белән кыздырылган форель балыгы алып килде.* Г.Исхакый. *Онега суын ошатканнар булса кирәк – севан форельләре анда бик әйбәт үрчи.* А.Муранов

**ФОРЗАЦ** *и. нем. махс.* Китап блогын тышы белән тоташтыра торган, икегә бөкләнгән кәгазь. *Аның [китапның] тышлыгы, форзацлары, заставкалары һәм нәфис миниатюрлар дәрәҗәсендәге иллюстрацияләре Надия Фәхретдинова тарафыннан эшләнгән.* Р.Әмирхан

**ФО́РМА** *и. лат.* 1) Әйбернең тышкы кыяфәте, күренеше; шәкел. *Богаз буендагы урамга чыксак, һәммә халык түшләренә ай-йолдыз формасындагы чәчәкләр кадаган.* А.Расих. *Цилиндр формасындагы, шома һәм кабыргасы ак, алтынсу яисә яшел төстәге озынча җимешләр бөтен җирдә дә игелә.* Мөселман календаре

2) *филос.* Эчтәлек белән тыгыз бәйләнешле төзелеш, рәвеш, эчтәлекнең конкрет гәүдәләнеше

3) Төр, үзенчәлек, стадия. --- *икмәк ашатмыйча, терлектән ит, май, сөт алып булмый, ләкин моның формалары уйланган, оештырылган, планлы булырга тиеш.* М.Мәһдиев. *Теләсә кайсы дин формасының нигезендәге кебек үк, тотемизмның психологик нигезендә дә кешеләр аңында аларның тормыш шартларының хыялый чагылышы ята.* Кызыклы психология

4) Билгеләнгән тәртиптәге стандарт үрнәк. *Доверенностьның мин сезгә классик формасын өйрәтим әле.* М.Мәһдиев

5) Нинди дә булса әйбергә билгеле бер рәвеш бирү өчен кулланыла торган җайланма, калып. *Кою цехында, хәйран калып, вагранкадан аккан металлның форма буйлап үзенә юл алганын күзәтәчәкмен.* А.Расих. *Чыңгыз белән Камил җиргә иңдереп ясалган формаларга металл коярга керештеләр.* Н.Хәсәнов

6) Аерым ведомствога караган бер үк төсле кием. *Ул әле яңа гына Казаннан кайтып төшкән, гимназистлар формасы кигән яшь егет иде.* А.Расих

7) Тышкы ялтыравык, тышкы күренеш, фасон. *Аның түш кесәләренә форма өчен кургашын бөкеле патроннар тезелгән.* К.Нәҗми. --- *рәсми бәяләрдә әсәрләрнең бары тик идея ягына гына игътибар ителүе, социальлектән гайре башка сыйфатларга илтифат күрсәтелмәве дә форманы үзмаксат итеп куюга китерде.* Ф.Галимуллин

8) *лингв.* Билгеле грамматик ысул белән даими, стандарт рәвештә грамматик мәгънә белдерелгән тел билгесе. *Безнең фикеребезчә, төрки тел ике мең ел элек үк диярлек грамматик төзелеш ягыннан камиллеккә, грамматик формаларның, фонетикасының, морфологиясенең гадилегенә ирешкән.* Ә.Кәримуллин. *Ләкин юнәлеш категориясенең форма ясаучы кушымчалары һәм лексик-грамматик категория тәшкил иткән эш-хәрәкәт ысулы кушымчалары – мөстәкыйль фигыль ясаучылар, дип карала.* Татар грамматикасы

◊ **Формага кертү** Тиешле рәвешкә китерү, тәртипкә салу. *Яз җитә башлагач, күпләр тиз генә ябыгу, гәүдәне формага кертү, артык майларны бетерү турында хыяллана башлый.* Әлки хәбәрләре. **Формага керү** 1) Төрле төс, кыяфәт, рәвеш алу. *Бакыркош белән Шүрәле – роботлар, параллель планетаның бүгенге хуҗалары. Алар, төрле формага кереп, төрле затларга әверелергә сәләтле.* А.Тимергалин; 2) *спорт* Ярышларда катнаша алырлык хәлгә килү, югары әзерлеккә ирешү, күнекмәләр алу. **Формага салу** *к.* **формага кертү**. *Шушы катлаулы бай эчтәлек мәкальдә җыйнак формага салып бирелә.* Х.Мәхмүтов. **Формада булу** *спорт* Әзерлеклелек дәрәҗәсе югары булу. *Атказанган спорт мастеры, самбист Харлампиев ярышлар алдыннан авырып китә, тик шулай да ул ярышларда катнашудан баш тартмый, алай гына да түгел, бөтен кешенең гаҗәпләнүенә каршы, шундый әйбәт формада була.* Кызыклы психология. **Формасын китерү** Килештерү, охшату. *Ләкин бик бай сыман киемле Хөсәен һәм формасын китереп барган кучер шик кузгатмады булса кирәк.* Казан утлары

**ФО́РМАЛАУ** *ф.* Калыпка салу, форма бирү. *Аңарчы Татарстан дәүләт нәшриятында китапларны формалау һәм сурәтләү эшләре махсус квалификацияле художниклар кулында түгел иде.* И.Лобашева

**Формалап чыгу** Һәрберсен, берәмберәм ахырга кадәр формалау

**ФО́РМАЛАШТЫРУ** *ф.* 1) Тиешле, төгәлләнгән формага китерү. *Пётр I язган указында үзе төзегән регуляр армия рекрутларына карата таләпләрне кыска һәм ачык итеп формалаштырган.* Кызыклы психология

2) Законлаштыру, рәсмиләштерү. *Әтигә сигез йөз сумнан азрак акчаны, мең итеп кайтару шарты белән, документаль формалаштыралар.* А.Расих

3) *күч.* Шәхес буларак үстерү, үзенә хас сыйфатларның камилләшүенә ирешү. *Такташны Такташ итеп формалаштырган традицияләрне ачыклаганда, --- әдәбиятчылар, педагоглар иң элек шагыйрьнең лирикасына мөрәҗәгать итәргә тиешләр.* Г.Гыйльманов

**Формалаштыра бару** Торган саен ныграк, күбрәк формалаштыру. *Бер үк вакытта шагыйрь [Р.Харис] төрле йогынтыларны җиңә һәм үз иҗади шәхесен формалаштыра бара.* М.Вәлиев

**Формалаштыра башлау** Формалаштырырга керешү. *Әлеге чорда, ул [Тициан] Микеланджело белән Рафаэль әсәрләрен җентекләп өйрәнү нәтиҗәсендә, үзенә генә хас алымнар, стилистик сыйфатлар формалаштыра башлый.* К.Гыйззәтов

**Формалаштыра төшү** Бераз формалаштыру

**Формалаштырып бетерү** Ахырга кадәр барысын да формалаштыру. *--- югары уку йортында биш ел белем алу гына кешенең дөньяга карашын формалаштырып бетерә алмый.* К.Миңнуллин

**Формалаштырып килү** Озак вакыт дәвамында эзлекле рәвештә формалаштыру. *Кадими татар мәктәбе --- дәүләтнең христианлаштыру һәм руслаштыру сәясәтенә каршы торырлык мөселман рухи-әхлакый нигезле шәхесләр формалаштырып килде.* Ватаным Татарстан

**Формалаштырып тору** Һәрвакыт, гел формалаштыру. *Әлеге үсемлекнең ябалдашларын гел формалаштырып торырга кирәк.* Безнең гәҗит

**Формалаштырып чыгу** Һәрберсен, берәм-берәм ахырга кадәр формалаштыру

**ФО́РМАЛАШУ** *ф.* 1) Билгеле бер формага керү, нинди дә булса рәвеш алу. *Һава пары камил геометрик сурәтле кар бөртеге булып формалаша*

2) Оешу, төзелү. *--- җәмгыятьне оештыруның сәяси формасы булган дәүләт формалаша.* Д.Сабирова. *Акрынлап православие һәм ислам цивилизацияләренең территориясе формалаша.* Татарстан яшьләре

3) Барлыкка килү, ясалу. *Төрки телләрдә саннар формалашу тарихында «күплек» төшенчәсе өчле, бишле, җиделе һәм соңыннан унлы саннары аркылы килә.* Л.Җәләй. *Дүртенчел чор башында, миллион еллар элек, хәзерге Байкал формалашкан.* А.Муранов

4) Җитлегү, үсү, тиешле дәрәҗәгә ирешү. *Тарихчы галим буларак Ибраһимов Бөек Октябрьдән соң формалашты.* М.Хәсәнов. *Кеше затына бирелгән сәләтләр фәкать социаль факторлар булганда гына тулы рәвештә ачылалар, --- шушы шартларда индивидның акыл сыйфаты формалаша.* К.Гыйззәтов

**Формалаша бару** Торган саен ныграк формалашу. *Анда [әсәрдә] тормыш юлына әле генә аяк баскан яшьләрнең хезмәт эчендә --- мөстәкыйль шәхес булып формалаша барулары тасвирлана.* Татар әдипләре

**Формалаша башлау** Формалашырга керешү. *Кайчандыр бердәм булган Җүчи олысының көнчыгыш өлешендә Нугай Урдасы барлыкка килә, һәм Себер, Үзбәк һәм Казак ханлыклары формалаша башлый.* Б.Хәмидуллин

**Формалашып бетү** Тәмам, тулысынча формалашу. *XX йөзнең беренче дистә елларында татар милли матбугат челтәренең формалашып бетүенә китерә.* Д.Исхаков

**Формалашып җитү** Тиешенчә формалашу. *Нәкъ шушы чорда татар милли әдәби теле формалашып җитте.* М.Хәсәнов. *Вена классик мәктәбе симфония, соната, концерт, квартет һ.б. жанрларның тәмам формалашып җитүен тәэмин итә.* К.Гыйззәтов

**Формалашып килү** Акрынлап формалашу. *Болгар хакиме, хәзерге Әфганстан киңлекләрендә формалашып килгән яңа төрки биләмә (тарихта ул «Газнәвиләр дәүләте» дип йөртелә) солтаны Мәхмүд Газнәвине яңа зур җиңүе белән котлап, махсус илчеләр җибәрә.* М.Гайнетдин

**ФОРМАЛИЗМ** *и. рус* 1) Эшнең асылыннан бигрәк, формаль ягын кайгырту, формаль таләпләр куеп мавыгу, бюрократлык. *Күп кешеләрнең уртак гаебе – битарафлык, тәрбия эшендәге формализм, гаиләдәге гамьсезлек, үсмерләргә гадел таләпчәнлек җитмәвенең черек җимешләре.* Ә.Хуҗиәхмәтов

2) *филос.* Этикада, сәнгать, әдәбият һ.б. фәннәрдә эчтәлекне инкяр итеп, фәкать формага гына әһәмият бирү юнәлеше. *Эчтәлекне икенче плангарак куеп, формализм йогынтысы белән мавыга башлыйсың.* Ф.Кәрим. *Егерменче елларның башларында татар әдәбиятына формализм йогынтысы килеп керде.* Х.Госман

**ФОРМАЛИН** *и. лат.* Дезинфекция ясау өчен кулланыла торган матдә; кырмыска кислотасының (формальдегидның) судагы эремәсе. *Колхозда орлыкка калган борчакны язын формалин сыекчасы белән эшкәртәләр иде.* М.Мәһдиев. *5 кашык баллы суга 1 кашык формалин һәм 3 кашык сөт салыгыз.* Йорт эшләре

**ФОРМАЛИНЛА́У** *ф.* Формалин сыекчасы белән дезинфекцияләү. *Терлек абзарларын формалинлау*

**ФОРМАЛИСТ** *и. рус* 1) Эш йөртүдә бары тышкы формаль якны гына

кайгыртучы кеше, хәреф корты, бюрократ. *Әгәр эш файдасына инструкция хәрефенә ябышып яту формализм дип бәяләнә икән, мин – формалист.* А.Гыйләҗев. *Бу чыганак һәм башкалары белән танышканнан соң --- тикшерүчеләрнең надан, формалист ялчылар ролен уйнаганын аңлый башлыйсың.* Рәмзи Вәлиев

2) Формализм (*2 мәгъ.*) тарафдары, форманы эчтәлектән аерып, аны беренче урынга куеп иҗат итүче кеше. *Музыка сәнгатендә формалист дип, Шостаковичка юнәлгән гаепләү чыгышларына тыныч кына карый алмый.* Ф.Галимуллин

**ФОРМАЛИ́СТИК** *с.* 1) Эштә, тормышта формаль якны беренче урынга куйган. *Эшкә формалистик мөнәсәбәт*

2) Формализмга (*2 мәгъ.*) нигезләнгән. *Формалистик трюклар ярдәмендә булса да күренергә, игътибарны җәлеп итәргә теләгән шагыйрьгә бу теория гаҗәеп кулай.* Ф.Галимуллин. *Формалистик алымнарга, риторикага һәм вәгазьчелеккә өлеш чыгаргаласа да, Туфан, нигездә, яшьлек һәм яңа тормыш романтикасына --- турылыклы булып калды.* Т.Галиуллин

**ФОРМАЛИСТЛА́РЧА** *рәв.* **1.** Формалистка, формализмга хас рәвештә. --- *алар русча текстны формалистларча механик рәвештә копияләп алмаганнар.* Х.Сарьян

**2.** *с. мәгъ.* Формализмга нигезләнгән. *Формалистларча мөнәсәбәт*

**ФО́РМАЛЫ** *с.* 1) Аерым үзенә хас формасы булган, өлге белән эшләнгән, калыпка салынган. *Кунак, шкаф белән сәер формалы прибор арасына кереп кысылган табуретканы эләктереп алып, койка янәшәсенә елышты.* Ф.Бәйрәмова. *XV гасыр урталарында Әстерханда, Кырымда сугылган озынча формалы акчаларны халык әҗгәрәй дип атап йөрткән.* А.Тимергалин

2) Аерым ведомствога караган, бер үк фасон белән тегелгән. *Аларның матур формалы киемнәренә карагач, Габделнур үзенең хәрби хезмәттә чагын исенә төшерде.* Р.Кәрами. *Формалы кием генә түгел, хокук тәртибен саклау эше дә миңа ошады.* Кызыл таң

3) Төрдәшләреннән үзенә хас үзенчәлеге белән аерылып торган. *Тукай кебек үк ачык формалы үпкә туберкулёзы белән интеккән, үз-үзен көчкә йөрткән Сәгыйть авыр физик хезмәт шартларында ачлык, хурлау-кимсетелүләр кичерә.* Кызыл таң

4) *лингв.* Парадигматик рәттә сүз төрләрен барлыкка китергән. --- *заманның бу мәгънәсендә контекстта үткәннең билгеле моментына ишарәләүче сүзләр булып вакыт рәвешләре яки -ды, -ган, -ганда формалы фигыльләр килә.* Ф.Хисамова

**ФОРМАЛЬ** *с.* **1.** 1) Формаларны аларның конкрет эчтәлеген исәпкә алмыйча өйрәнә торган; формага нигезләнгән; формага мөнәсәбәтле. *Формаль логика фикерләүнең кешеләргә хас бер хатасын күптән аңлады инде: ул хата бөтенне өлеш белән алыштырудан гыйбарәт, һәм аны өлешне абсолютлаштыру дип атыйлар.* Кызыклы психология. *Формаль система. Формаль тел белеме*

2) Рәсми, законлы, аерым стандарт формага нигезләнгән. *Шулай да, этимология күзлегеннән караганда, галим сайлаган вариантның (Сөен-бикә) формаль рәвештә дөресрәк булуы ихтималга якынрак.* М.Госманов. *Минә сезгә Борһановның авылга җибәрүне сорап язган гаризасы, хәзер үк, бер минут кичекми, хәл итегез. Һәртөрле формаль яклары бүген үк беткән булсын.* Г.Ахунов

3) *әд.* Эчтәлекне читтә калдырып, беренче урынга форманы куйган. *Формаль дип йөртелгән футуризм, имажинизм юнәлешләренең барлыкка килүе, аларның билгеле бер рәвештә оешканлык алуы иҗади эзләнүләргә мөмкинлек булуы турында сөйли иде.* Ф.Галимуллин

4) Форма өчен генә булган, күз буяу өчен эшләнгән, ясалма

**2.** *рәв. мәгъ.* Ясалма итеп, эчтәлеккә керешмичә. *Ә без ул чорда формаль сөйләшергә ияләнеп беткән идек – бик ансат кына җавап бирәсең: «Әйе, мин бәхетле, чөнки мин ирекле, азат илдә иҗат итәм».* М.Мәһдиев

**ФОРМАЛЬЛЕК** *и.* Тиешеннән артык таләпчәнлек, искергән, катып калган кануннарны сакларга тырышу. *Аларда безгә хас булган тышкы формальлек, дини фанатизм юк.* С.Ибраһимова

**ФОРМАНТ** *и. лат. лингв.* Кушымча, аффикс. *Күренә ки, фарсыларда -и форманты --- хәзер дә исемнәрдән – сыйфат, сыйфатлардан исем ясый.* Н.Максимов

**ФОРМАНТА** *и. лат. лингв.* Авазларның, башлыча сузыкларның акустик билгеләре җыелмасы. *Авазның спектрында берничә форманта була, тик лингвистика өчен беренче ике форманта аеруча әһәмиятле, ә калган формантлар сөйләүченең индивидуаль үзенчәлекләрен һәм башка билгеләрен генә чагылдыралар.* Татар грамматикасы

**ФОРМАТ** *и. лат.* 1) Китап, кәгазь, карточка һ.б.ш.ның тышкы өслеге үлчәме. *Күләме һәм форматына караганда, журнал һич тә әдәби түгел.* Р.Мирхәйдәров

2) *махс.* Набор полосасының озынлыгы, биеклеге, юл арасы. *Күләме 400 биттән артыграк булган әлеге әсбап текстны җыю һәм битләргә салу, иллюстрацияләр әзерләү, шрифт һәм формат сайлау, кәгазь хикмәтләре, бастыру, төпләү һ.б. турында тәфсилләп аңлата.* М.Вәлиев

3) *информ.* Мәгълүмат объектының билгеле структурасы. *Файлның форматы*

4) Берәр чараны оештыру, төзү, бирү үзенчәлеге, үткәрү рәвеше. *Ярышларның форматы. Халыкара очрашу форматы*

5) Телевидение, радио, кинематография һ.б.ш.да кулланылган чараларның техник характеристикасы һәм тапшыру стандарты, типажы. *Спорт тапшыруы форматында эшләү*

**ФОРМАТИВ** *и. лат. к.* **формант**. *Сан категориясенең берлек төре һәрвакыт нуль формада була, берлекнең үзенә аерым формативы юк.* В.Хангилдин

**ФОРМАТЛАНУ** *ф. информ. төш. юн. к.* **форматлау**. *Диск форматланмаган*

**ФОРМАТЛА́У** *ф. информ.* Каты диск, дискета һ.б.ш. электрон мәгълүмат саклагычларның мәгълүмат саклау өлешләрен билгеләп чыгу юлы белән мәгълүматка керү структуралары барлыкка китерү (бу вакытта кайбер элекке материаллар юкка чыгарыла). *С дискын форматлап ату белән проблема чишелде.* Р.Хәйруллин

**ФОРМА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Нәрсәнең дә булса үсешендә билгеле бер стадия, үзенчәлекле структура белән билгеләнгән чор. *Россия дәүләте үзенең үсешендә колбиләүчелек формациясен булдырмаган көе феодализмга чыкты, дип укыттылар безне.* М.Мәһдиев. *Иҗтимагый-икътисади формация. Капиталистик формация*

2) Эчке дөнья, карашлар системасы, мәсләк. *Элекке народникларның яңа формациясе булган социалист-революционерлар партиясе дигән сүз.* Г.Ибраһимов

3) *геол.* Аерым геологик чорда, дәвердә уртак юл белән барлыкка килгән җир катламнары, тау токымнары. *«Недро» нәшриятында чыккан «Магматик формацияләрнең төп типлары» һәм башка дәреслекләр буенча меңнәрчә студентлар белем алалар.* Казан утлары. *Вулканоген формация. Руда формациясе*

**ФО́РМАЯСАГЫЧ** *с. лингв.* Грамматик форма ясый торган. *Ояның баш сүзе туры кара хәрефләр белән бирелде, сүзьясагыч кушымчалар – кара юл хәрефләре, формаясагыч кушымчалар якты курсив белән аерылдылар.* И. Сабитова

**ФО́РМАЯСАЛЫШ** *и.* 1) Яңа формалар барлыкка килү күренеше

2) *лингв.* Бер сүзнең грамматик формалары ясалуы. *Шул рәвешчә, һәр ике төр кушымчалар формаясалышына карый.* Ф. Хисамова

**ФОРМО́ВКА** *и. рус* 1) Аерым форма бирү, формага, калыпка салу процессы

2) Форма, калып әзерләү эше

**ФОРМО́ВЩИК** *и. рус* Формовка белән шөгыльләнүче, шул эшнең белгече. *Бүген мәктәпнең югары сыйныфларында укучы яшьләрдән берсе дә слесарь, токарь, электрик, формовщик кебек һөнәргә өйрәнергә телим димәс, чөнки Русиядә соңгы унбиш-уналты елда эре промышленность предприятиеләренең күбесе я ябылды, я җитештерү азайды.* Татарстан яшьләре

**ФО́РМУЛА** *и. лат.* 1) Кыска һәм төгәл, үзгәрешсез кабул ителгән аңлатма, билгеләмә. *Тимирязев күптән инде дилетантлыктан да, белемнең берьяклылыгыннан да саклый торган формула бәян иткән иде.* Кызыклы психология. *Әйтик, мондый характердагы каршылык --- аталар белән балалар тартышы кебек классик конфликт формуласына килеп чыкса, «Тартышу» драмасында (1908) инде инкыйраз көчләренең гамәле, сыйнфый каршылыклар формасын алып, шактый җитди сәяси фон тудыра.* Мирас

2) Теләсә нинди кагыйдәнең, мөнәсәбәтләрнең, законның бөтен очракларда да кабатлана торган төгәл, гомуми билгеләмәсе. --- *егерме, алтмыш, җитмеш, сиксән, туксан дигәндә, аларның компонентлары унарлы система формуласы буенча төзелгәне ачык исбат ителә.* Л.Җәләй

3) *мат. физ.* Шартлы тамгалар ярдәмендә күрсәтелгән математик закон. *Мәсьәләне чишкәндә нинди формулага нигезләнеп чишәргә икәнен искәртә.* В.Нуруллин. *Хәмит баш җитмәс физик формулалар кыстыра-кыстыра сөйли башлагач, кыз карашын аңа күчерде.* Р.Вәлиев

4) Химик элементларны, аларның составын, төзелешен, төрле химик процессларны күрсәткән, шарты хәрефләрдән һәм саннардан торган төгәл билгеләмә. *Аш тозы формуласы. Яну формуласы*

**ФОРМУЛИРО́ВКА** *и. рус* 1) Нәрсәнең дә булса төгәл билгеләмәсе, аңлатмасы. *Мондый формулировка Ленинның пролетариат диктатурасы тәгълименә каршы.* Ф.Галимуллин. *Яшереп кенә алып килгән тычканны җибәреп, укучы дәресне өзгән: тәртибе өчен икеле алган – бу формулировка дөресме соң?* Кызыклы психология

2) Фикернең, уйның кыска һәм анык тупланып бирелүе, бирелеш формасы

**ФОРМУЛЯР** *и. нем.* 1) Корылманы, механизмны, приборны эксплуатацияләү, аның эшкә яраклылыгы, төзеклеге турында мәгълүматлар язылган белешмә китап, кенәгә

2) Китапханәдә: исәпкә алу, теркәү, учёт карточкасы. *Дәүләт китапханәләренә йөрүче 5 мең кешенең нинди әсәрләр укуы анализланды. Формулярлары карап чыгылганнан соң, анкета сорауларына җавап биргән укучыларның күпчелеге – 30 яшькә җитмәгән кешеләр.* Казан утлары

**ФОРПОСТ** *и. нем.* 1) *хәрби* Ныгытылган алгы позиция, алгы пост, аванпост

2) *күч. кит.* Берәр әһәмиятле эштә таяныч, алдынгы маяк. *Монастырь исә теләсә нинди фетнәчеләргә, шивәчеләргә каршы көрәшү өчен форпост булып хезмәт иткән.* З.Фәтхетдинов

**ФОРСАТ** *и. гар.* Уңайлы очрак, җай, мөмкинлек. *Качыгыз, кач, матурлар, качыгыз форсат бар чакта.* Дәрдемәнд. *Виктор Иванович минем хикәяткә бик җитди карады, галимнәрнең күлне өйрәнү өчен шундый форсаттан файдалана алмый калуларына уфтанып та куйды.* Р.Мостафин

◊ **Форсат бирү** Уңайлык, мөмкинлек тудыру. --- *сугыш вакытында Дойчландта тыныч яшәргә форсат биргәннәр икән, бу инде бәхет елмаюы дигән сүз.* Т.Әйди. **Форсатны качыру** Файдалану өчен иң уңайлы очракны, моментны уздырып җибәрү, моменттан файдалана алмый калу. *«Үзенеке ташламас, ят ярлыкамас» диләр бит, бүтән урыс эшчеләр дә, татар, чуашлар белән сугышу урынына, форсатны качырмыйча, җыелган түрә, начальникларны кыйнаганнар.* А.Таһиров. **Форсатны кулдан ычкындыру** *к.* **форсатны качыру**. *Әсирлеккә эләккәннән соң беренче мәртәбә кешегә ял итәргә мөмкинлек туган икән, форсатны кулдан ычкындыру – гөнаһ, дип уйлап, тиз генә чишенеп, зәңгәр җәймәнең буш ягына тәгәрәде.* Т.Әйди. **Форсат чыгу** Мөмкинлек туу, уңай очрак килеп чыгу. *Соңгы елларга кадәр ул [Дәүләкән] гел искә төшә торды, һаман мине үзенә тартты. Һәм мин, форсат чыккан саен, я электричкада, я машинада чакырылмаган кунактай барам да төшәм.* Ә.Еники. *Әгәр берәрсе, форсат чыгып, шундый мөмкинлеккә ия була икән, ул анда бару хакында тәфсилләп сөйли.* М.Мәхмүтов

**ФОРС-МАЖОР** *и. фр.* Бизнеста: якларның эшчәнлегенә бәйләнмәгән, килешү, шартнамәләр төзегәндә алдан билгеләргә мөмкин булмаган (табигый афәтләр, иҗтимагый хәрәкәтләр, сәяси хәл үзгәрү h.б.) шартлар

**ФОРСУ́НКА** *и. ингл. махс.* Тузан, сыеклык хәлендәге ягулыкны, тиз һәм тулысынча янып бетсен өчен, көчле өрдереп тарката торган бер яки берничә тишекле җайланма. – *Сул як топканың форсунка торбасы шартлады, аккан мазутка ут капты, – дип хәбәр иттеләр.* С.Сабиров

**ФОРТ** *и. нем. хәрби* Кальга корылмалары алдында яки эчендә хәрби көчләрне саклау яки һөҗүм итүне җайлаштыру өчен эшләнгән аерым, мөстәкыйль, көчле ныгытма. *Уңда гаять зур бетон фортлар, болары – британ хөкемдарлары калдыклары.* Р.Мостафин. *Франциянең камап алынган Бола фортына бер күгәрчен күп тапкырлар почта китерә.* Кызыклар дөньясында

**ФО́РТЕ** *рәв. ит. муз.* Иң көчле тавыш белән

**ФОРТЕПИА́НО** *и. ит. муз. к.* **фортепьяно**. *Людвиг Бетховен гомере буе яшь, чибәр кызларга гашыйк булып яшәгән, кайберләрен фортепиано уйнарга да өйрәткән.* Т.Әйди. *Фортепиано исә, тегеләренә дә, боларына да төп уй-фикерне төшендерергә һәм ахыр нәтиҗәне чыгарырга теләгәндәй, тыңлаучыга асыл мәгънәләрне ирештерә.* Казан утлары

**ФОРТЕПЬЯ́НО** *и. ит. муз.* Кыллы бәрмә клавишлы музыка коралларының

гомуми исеме (пианино, рояль). *Салихның шәкерте фортепьянода уйный ---. Танышу йөзеннән, без әле менә туташны уйнатып та, җырлатып та карадык.* Ә.Еники. *Шул чорда ук Фәрит Яруллин виолончель һәм фортепьяно өчен соната --- яза.* Казан утлары

**ФОРТЕПЬЯ́НОЧЫ** *и.* Фортепьянода уйнаучы

**ФОРТИФИКАЦИОН** *с. лат. хәрби* Хәрби ныгытмаларга караган, шулар белән бәйле; оборона корылмасы булган. *Бу сүзләрдән Казан кремленең стеналары белән манараларының архитектур кыйммәте генә түгел, бәлки зур фортификацион әһәмияте дә бик нык сизелә.* Милләт календаре

**ФОРТИФИКА́ЦИЯ** *и. лат. хәрби* 1) Сугыш мәйданын ныгыту, оборона корылмалары турында хәрби инженерлык фәне

2) Хәрби инженерлык ныгытмалары төзү эше һәм шул ныгытмалар үзе. *Сайлый белгәннәр шәһәр урынын: ярлар текә, табигый фортификация, дошманнан саклануны Аллаһы Тәгалә алдан хәл итеп куйган.* М.Юныс

**ФО́РТОЧКА** *и. нем.* Һава алмаштыру өчен тәрәзәдәге кечкенә пыяла ишек, җиллек. *Ул форточкаларны ачты, күлмәк якасындагы өске төймәне ычкындырды, әмма сулыш алу җиңеләймәде.* Р.Вәлиев. *Тузан керер, җил чыкса, форточканы ачмагыз.* З.Гомәрова

**ФОРТУ́НА** *и. лат.* 1) Борынгы Рим мифологиясендә уңыш алиһәсе

2) Хәерле язмыш, тәкъдир, бәхетле очрак. --- *фортуна, – хатын-кыз кебек ук, яшьләрнең дусты, ә яшьләр исә артык саклык белән эш итмиләр, фортунаны кыюлык һәм кайнар дуамаллык белән кулга иялəштерәләр.* Н.Макиавелли

◊ **Фортуна елмаю** Уңай форсат чыгу. *Кем белә, бәлки, сиңа фортуна елмаеп куяр.* Т.Нәбиуллин. **Фортуна җиле** Язмыш, тәкъдир. --- *вакыйгалар башка тарафка борылса яки фортуна җиле башка якка таба исә башласа, падишаһ гамәлләр юнәлешен үзгәртергә күңеленнән һәрвакыт әзер торырга тиеш.* Н.Макиавелли

**ФО́РУМ** *и. лат.* 1) *тар.* Борынгы Римда иҗтимагый тормыш үзәге булган мәйдан. *Римны күргән кеше хәтерли торгандыр: форум янындагы Капитолий калкулыгына күтәрелер алдыннан, игезәк балаларны имезеп торучы таш бүрегә кадәр, читлектә тотылган тере бүрегә юлыгасың.* М.Юныс

2) Массакүләм җыелыш, съезд. *Олы форум Россия Дәүләт Думасы рәисе, «Правда» газетасының элеккеге баш редакторы Геннадий Селезнёв чыгышы белән башланып китте.* Т.Нәҗмиев. *Ә форумның максаты – бөтен прогрессив татар яшьләрен тынычлык, демократия, прогресс өндәмәсе җирлегендә берләштерү.* Сөембикә

**ФОРШЛАГ** *и. нем. муз.* Башкару вакытында төп мотивка кушылып башкарылган, бер яки берничә яңгырашлы музыкаль бормалардан торган бизәкләр. *Өченче мотив исә, киресенчә, форшлаг аша секстага күтәрелеп, ре буйлап квинтага төшә.* Х.Курбатов. *Бу, бигрәк тә, мелизмнар, форшлаглар, мордентлар һәм башка бизәкләр күп булган татар музыкаль фольклорына кагыла.* Фәнни Татарстан

**ФОРШМАК** *и. нем.* Тапалган иткә яки балыкка төрле очракларда бәрәңге, суган, әче алма, пешкән йомырка, каймак, тоз, борыч һ.б. кушып әзерләнгән кайнар яки салкын ашамлык. *Форшмак пешерү*

**ФОРШТЕ́ВЕНЬ** *и. голл. диң.* Судноның борын өлеше. *Кыз чибәр, форштевень дисеңме, ахтерштевень дисеңме – барысы да үз урынында.* М.Мәһдиев

**ФОСГЕН** *и. гр. хим.* Хлорның углерод оксиды белән кушылуыннан барлыкка килә торган, тын юлларын агулый торган төссез газ. *Фосген --- гидролизы продуктын нейтральләштерү өчен, 27,5 мл --- селте эремәсе киткән.* Г.Хисамиев

**ФОСФАТ** *и. гр. хим.* Фосфор кислотасы тозы (медицинада, техникада һәм ашлама буларак авыл хуҗалыгында кулланыла). *Инде бераз сәламәтлегемне карыйм дип дәваханәдә анализлар тапшырган идем, бәвелемдә фосфатларның күп булуы ачыкланды.* Сәхнә

**ФОСФАТЛА́У** *ф.* Фосфат кертү, фосфат кушу

**ФОСФАТЛЫ** *с.* Составында фосфат булган. *Татарстан экология министры халыкны фосфатлы юу чараларын кулланмаска өндәде.* Саба таңнары

**ФОСФАТУРИ́Я** *и. лат. мед.* Сидек белән бергә зур күләмдә фосфор кислотасының тозлары бүленеп чыгу

**ФО́СФОР** *и. гр.* Кайбер минералларда, сөяктә, хайван һәм үсемлек тукымаларында булган, тиз кабынып китә, караңгыда үзеннән яктылык чыгара торган химик элемент. --- *күпме хайван агуланып, үләксә базлары өстендә җәй буе фосфор ялкыннары биеште.* Ә.Гаффар. *Фосфор җитешмәгәндә яфраклар ваклана, вакытыннан элек коела.* Бакчачы, яшелчәче һәм умартачы календаре

**ФОСФОРЕСЦЕ́НЦИЯ** *и. ингл. физ.* Кайбер матдәләрнең үзенә юнәлтелгән нурлар тәэсирендә, ул сүнгәннән соң яктылык чыгару үзлеге. *Фосфоресценция тудыра торган матдәләр – --- кристаллофосфорлар ---.* Физика

**ФОСФОРИТ** *и. гр.* Составында фосфор булган, фосфатлар группасына кергән минерал. *Фосфорит онында фосфор микъдары гади суперфосфаттагы кадәр үк диярлек, тик ул суда эреми һәм кертелгән елда үсемлекләр тарафыннан начар үзләштерелә.* Бакчачы, яшелчәче һәм умартачы календаре. *Миас бассейнында ташкүмернең шактый зур запаслары, фосфорит һәм каолин ятмалары бар.* Чит илләрнең экономик географиясе

**ФО́СФОРЛЫ** *с.* Составында фосфор булган, фосфор кушылган. *Америкaн туплары фосфорлы ядрәләр ата, ул төшеп ярылган җирдә ындыр табагы кадәр зур, тирән чокыр хасил була.* Т.Әйди. *[Күлдә] Сарык тәкәсе кадәр карплар фосфорлы күзләре белән без күрмәгәннәрне күрә-күрә йөзәләр.* М.Мәһдиев

**ФОТ** *и. гр. физ.* Өслекнең яктыртылу дәрәҗәсен үлчәү берәмлеге

**ФОТА́РИЙ** *и. гр.* Ультрамиләүшә һәм җылылык нурлары белән яктыртып дәвалау кабинеты

**ФО́ТО** *и. гр. сөйл.* Фоторәсем. *Аның гримда реквизит костюмнан төшкән фотолары миндә әле дә саклана.* А.Расих. *Бергә төшкән Ялта фотоларында ул да бар.* А.Гыйләҗев

**ФОТО-** *и. гр.* Кушма сүзләрдә «фотография белән бәйле» мәгънәсендәге беренче компонент

**ФОТОАЛЬБОМ** *и. гр.-фр.* Фоторәсемнәр альбомы. *Кайчан килә аласың соң, фотоальбомны карап, Ирек турында төпченгән кешене ачыклыйсы бар иде.* М.Насыйбуллин

**ФОТОАППАРАТ** *и. гр.-лат.* Фоторәсемгә төшерү аппараты. *Ә магнитофон, фотоаппарат, сәгать, джинсы чалбар кебек әйберләрне студентлар һәм тирә-күрше дус-ишләренә биреп саттырганнар.* Х.Вәлиәхмәтов. --- *кулымдагы коралым да мылтык түгел, гап-гади фотоаппарат.* И.Гайфуллин

**ФОТОАУЧЫ** *и. к.* **фотосунарчы**. *Фотоаучы өчен бу – бик сирәк очрый торган хәл.* И.Гайфуллин

**ФОТОБО́МБА** *и. гр.-фр.* Караңгыда һавадан рәсемгә төшергәндә яктырту өчен ыргытыла торган махсус яктырткыч бомба

**ФОТОВИТРИ́НА** *и. гр.-фр.* Фоторәсемнәрдән торган витрина. *Урамга күрсәтеп куйган фотовитринасында чибәр-чибәр кызлар, купшы-купшы егетләр яки Казанның атаклы кешеләре төшерелгән төрле зурлыктагы карточкалар портретка төшәргә чакырып торалар.* М.Әмир

**ФОТОГРАВЮ́РА** *и. гр.-фр.* Фотоаппарат белән төшерелгән рәсемне металл пластинкага күчерү ысулы һәм шул пластинкадагы рәсем

**ФОТОГРАММЕ́ТРИЯ** *и. гр.* 1) Фотографик сурәтне үлчәп, аның чынбарлыктагы зурлыгын, пространстводагы торышын ачыклау

2) Фоторәсем буенча җир өстенең планын төзү

**ФОТО́ГРАФ** *и. гр.* Фоторәсемгә төшерүче, фотография эше белгече. *Ул миңа үзенең кызыксынучанлыгы, техника белән җенләнүе аркасында ошый. Ул – фотограф та, радио сөюче дә.* А.Расих. *Туганнары Рәшит белән Наҗиянең сурәтләрен янәшә куеп, фотографтан зурайттыралар, кыз чигеп биргән кульяулыкны шунда ук беркетеп куялар.* Р.Камалетдинова

**ФОТОГРА́ФИК** *с. гр.* **1.** 1) Фотографиягә мөнәсәбәтле. *Күзенә алтын читле күзлек, муенына зур фотографик аппарат тага.* Г.Исхакый

2) Фоторәсемгә төшереп алынган. *Фотографик рәсемнәр күргәзмәсе*

3) *күч.* Бик анык, төгәл, фоторәсемгә төшерелгән кебек. *Язучы кайдадыр, кайчандыр үзе күргән кирәк детальләрне, фотографик төгәллек белән кабатлап, күз алдына китереп бастыра ала.* Р.Фәйзуллин. *Ләкин ул [образ] фотографик сурәт түгел, ул – үзе тормыштан алынса да, язучы хыялы белән өр-яңадан барлыкка китерелгән тормыш картинасы.* Х.Сарьян

**2.** *рәв. мәгъ.* Бик төгәл тасвирлап. *Фотографик сурәтләү*

**ФОТОГРА́ФИЯ** *и. гр.* 1) Яктылыкка сизгер тасмага, пластинкага яки матрицага кайтарылган нурларның оптик җайланма аша тәэсир итү юлы белән сурәт алу эше. *Уфада яшәүнең соңгы елларында Габдулла Фәйзи фотография, радиотехника белән мавыга, хәтта үзе радиоалгыч җыя.* М.Әхмәтҗанов. *Фотография пластинкасының яктыртылуы камера эчендә кергән яктылык агышына һәм пластинканың объективтан күпме ераклыкта булуына бәйләнгән.* Физика курсы

2) Шул юл белән алынган сурәтнең үзе. *Фотография кую өчен фанердан челтәрләп рам ясау*

3) Шундый сурәт алу йорты, фоторәсемгә төшү бинасы. *Ләкин ул, фотографиягә барганда, үзенең әнисенең туган көне тугры килгәнгә генә кергән иде.* Г.Исхакый

**ФОТОЖЕЛАТИН** *и гр.-фр.* Фототасманың яктылыкка сизгер эмульсион катламын ясауда кулланыла торган койкасыман матдә. *Татарстанның иң әһәмиятле промышленность тармаклары булып нефть, химия, фототасма, фотожелатин, машина төзү, җиңел промышленность тармаклары санала.* Кызыклы география

**ФОТОЖУРНАЛИСТ** *и. рус* Әдәби-публицистик язмаларны фотографияләр белән тулыландыра торган, газета-журналларда эшләүче фотограф хезмәткәр. *«Идел-Пресс» нәшриятының уникенче катында Казан фотожурналистларының хезмәтләре куелган күргәзмә эшли.* Татарстан яшьләре

**ФОТОЗУРАЙТКЫЧ** *и.* Фототасмадагы сурәтнең күчермәсен ясаганда шул сурәтне зурайта торган аппарат

**ФОТОКА́РТОЧКА** *и. рус* Фоторәсем, фотографик юл белән алынган сурәт. *Катыргы белән тышлап, беренче битенә фотокарточкамны ябыштырып, бик матурлап, бизәп язган шигырь китапларым дүртәү булды.* Г.Афзал. *Ул кулындагы сумкасыннан фотокарточкалар төргәге алып, Бәхтияровка тоттырды.* М.Насыйбуллин

**ФОТОКӘГАЗЬ** *и.* Яктылык белән тәэсир итеп фототасмадагы сурәт күчерелә торган кәгазь. *Негативтан фотокәгазьгә күчергәч, анда уңнан сулга мондый сүзләр укыла ---.* Татар грамматикасы

**ФОТОКЕРА́МИКА** *и. гр.* 1) Керамик әйберләргә фотография юлы белән сурәт төшерү ысулы

2) Шул ысул белән эшләнгән әйбернең үзе

**ФОТОКО́ПИЯ** *и. гр.-лат. к.* **фотокүчермә**. *Цензор тарафыннан туктатылган китапның басыла алган беренче табакларыннан дүрт битнең үз үлчәвендә фотокопиясен алдырдым.* Г.Ибраһимов. *Ул, әни, фотокопия була, андый әйбер конкурска бармый.* Ә.Галиев

**ФОТОКОРРЕСПОНДЕНТ** *и. гр.-нем.* Вакытлы матбугатта чыккан фоторәсемнәрнең авторы, шунда эшләүче фотограф. *Шунда фотокорреспондентлар, тележурналистлар, радиожурналистлар мәш килә.* Т.Миңнуллин. *Без фотокорреспондент белән чемпион кызларыбыз янында булдык.* Сөембикә

**ФОТОКҮЧЕРМӘ** *и.* Фотографик юл белән алынган күчермә. *Ул исә гарәп хәрефендәге фотокүчермәне, инглиз телендәге аңлатмасын язып, Венгриядә бастырып чыгарды.* Х.Бәдретдинов. *Киңрәк сөйләр өчен, ул вакытта алар кулында әсәрнең фотокүчермәсе булмый.* Татар әдәбияты тарихы

**ФОТОЛАБОРАТО́РИЯ** *и. гр.-лат.* Фоторәсем ясау өчен махсус җиһазландырылган бүлмә

**ФОТОЛИТОГРА́ФИК** *с.* Фотолитография юлы белән эшләнгән

**ФОТОЛИТОГРА́ФИЯ** *и. гр.* Фотографиягә нигезләнгән литография (ташбасма)

**ФОТОМАТЕРИАЛ** *и. гр.-лат.* 1) Фотография шөгыле өчен кирәк булган материаллар. *Фотоматериал сатып алу*

2) Билгеле бер максатта файдаланыла торган фоторәсемнәр. *Анда төрле-төрле китапларның, альбомнарның, төпләнмәләрнең, кульязмаларның, фотоматериалларның һ.б. иге-чиге юк.* Р.Әмирхан. *Мин аңа үземдә саклаган фотоматериалларны бирдем.* Г.Таһиров

**ФОТО́МЕТР** *и. гр.-фр.* 1) *физ.* Яктылык көчен үлчи торган прибор

2) *астр.* Йолдызларның яктылык дәрәҗәсен билгели торган прибор

3) *хим.* Матдәләрнең химик составын билгеләү өчен кулланыла торган прибор. *Билгеле, ялкынлы фотометр хәзерге медицинаның соңгы сүзе түгел, ләкин Гөлшәһидә үзе дә аны беренче адым дип кенә карый әле.* Г.Әпсәләмов

**ФОТОМЕ́ТРИК** *с.* Фотометриягә бәйле

**ФОТОМЕ́ТРИЯ** *и. гр.-фр.* 1) *физ.* Оптиканың яктылык көчен үлчәү белән шөгыльләнә торган тармагы

2) *астр.* Астрономиядә йолдызларның яктылык дәрәҗәсен билгеләү белән шөгыльләнә торган тармагы

**ФОТОМЕХА́НИК** I *и. рус* Фотоҗайланмалар белән эш итүче кеше

**ФОТОМЕХА́НИК** II *с. махс.* Фотомеханикага караган

**ФОТОМЕХА́НИКА** *и. гр. махс.* Рәсемнәрнең күчермәләрен алуда кулланыла торган фотографик, химик ысуллар һәм җайланмалар җыелмасы

**ФОТОМОДЕЛЬ** *и. гр.-лат.* 1) Манекен; рекламалар өчен сайлап алынган фотографиягә төшүче

2) Типларын, маркаларын рекламалау өчен фотога төшерелгән әйбер. *Монда төрле вакытларда эшләнгән моторларның фотомодельләре, рәсемнәре рамлап эленгән.* Н.Хәсәнов

**ФОТОМОНТАЖ** *и. гр.-фр.* Берничә фоторәсемне бер бөтен итеп берләштереп ясалган уйдырма фотографик рәсем. *Уртада – күренекле кешеләрнең фоторәсемнәреннән эшләнгән фотомонтаж белән бизәлгән трибуна.* Д.Шәрәфетдинов

**ФОТОН** *и. гр. физ.* Яктылык кисәкчәсе, яктылык кванты. *Күздәге рецептор күзәнәкләрнең антенналары яктылык энергиясенә – фотоннарга җавап кайтара.* Кызыклы физиология. *Квант теориясе буенча, матдәнең атомнары һәм молекулалары яктылыкны, тоташ агым рәвешендә түгел, билгеле бер зурлыктагы аерым-аерым порцияләр белән генә чыгаралар яки йоталар. Яктылыкның ул аерым порцияләре яктылык квантлары яки фотоннар дип атала.* Физика курсы

**ФОТООБЪЕКТИВ** *и. гр.-лат.* Фотоаппаратның сурәтне җыеп бирә торган оптик җайланмасы. *Фотообъектив шактый күп кешене әләктергән.* Г.Әпсәләмов

**ФОТОПЛЁНКА** *и. гр.-чех к.* **фототасма**. *Шуларның берсендә фотоплёнкалар яшерелгән.* Р.Мөхәммәтҗанов. *Ул язуны фотоплёнкага (негативка) төшереп алып кайта.* Татар грамматикасы

**ФОТОРАЗВЕ́ДКА** *и. рус* Нинди дә булса территорияне, җирлекне фотога төшереп тикшерү разведкасы

**ФОТОРӘСЕМ** *и.* Фотографик рәсем, фотокарточка, фотография (*2 мәгъ.*). *Фоторәсемдә җәйге башкорт ишегалдының бер почмагы күрсәтелгән.* Ә.Еники. *Безнең гаилә альбомында аның студент формасы киеп төшкән бер фоторәсеме саклана.* А.Расих

**ФОТОРЕЛЕ** *и. гр.-фр.* Электр чылбырын яктылык нурларының тәэсире белән аера яки куша торган яктылыкка сизгер җайланма, прибор. *Фотореле-лар шәһәр урамнарындагы фонарьларны, маякларның, бакеннарның лампаларын кирәк моментта сүндерә һәм яндыра алалар.* Физика курсы

**ФОТОРЕПОРТАЖ** *и. гр.-фр.* Вакыйгаларны сурәтләгән фоторәсемнәр тезмәсе. *Дусның хәлен белеп, урып җыю турында фоторепортаж әзерләп кайтыйм дип, әлеге хуҗалыкка килдем.* Кызыл таң

**ФОТОРЕПОРТЁР** *и. гр.-фр.* Фоторепортаж әзерләү белән шөгыльләнүче фотограф

**ФОТОРЕПРОДУ́КЦИЯ** *и. гр.-лат.* Фотография юлы белән сурәтнең күчермәсен алу, аны күбәйтү, шул юл белән алынган сурәтнең үзе. *«Яшь галим»нең фоторепродукциясе шәһәр газетасында басылып чыкты.* Ә.Галиев

**ФОТОРО́БОТ** *и. гр.* Кешенең тел-дән тасвирлау нигезендә ясалган портреты. *Фоторобот буенча Нургали абзыйны эзләп табуы кыен булмастыр.* Т.Галиуллин

**ФОТОСИ́НТЕЗ** *и. гр. биол.* Хлорофиллы үсемлекләрдә яктылык көче ярдәмендә һавадагы яки судагы углекислотадан органик кушылмалар барлыкка китерү процессы. *Фотосинтез гомумән органик матдә хасил итүдә һәм шулай ук кешелек дөньясын бик зур күләмдә азык белән тәэмин итүдә әһәмиятле урын алып тора.* Җир һәм туфрак. *Җәй башында үсемлекләр яшел яфракка төренер, бу исә вегетация ахырына кадәр аларның су алмашын һәм фотосинтезын тәэмин итәр.* Бакчачы, яшелчәче һәм умартачы календаре

**ФОТОСТАТ** *и. гр.* Фотокүчермә ясый торган машина

**ФОТОСУНАРЧЫ** *и.* Кыргый хайваннарның тормышын, үз-үзләрен тотышын табигатьтә күзәтеп, аларны фоторәсемгә төшереп йөрүче фотограф. *Аеруча уңышлы чыккан рәсемнәрне фотосунарчылар күргәзмәсенә бирәм.* И.Гайфуллин

**ФОТОСУНАРЧЫЛЫК** *и.* Фотосунарчы эшчәнлеге, фотосунар белән шөгыльләнү эше. *Алар миннән киңәш сорыйлар, фотосунарчылык һөнәренә өйрәтүемне үтенәләр.* И.Гайфуллин

**ФОТОСУРӘТ** *и. к.* **фоторәсем**. *--- узышлый, стенага эленгән бер фотосурәт каршында туктап кала.* Н.Хәсәнов. *Менә шул язуның фотосурәте һәм андагы рун хәрефләренең халыкара транскрипция билгеләренә күчерелү схемасы.* Татар грамматикасы

**ФОТОСУРӘТЧЕ** *и. к.* **фотограф**. *Талантлы фотосурәтче Дамир Юсуповның иҗат җимешләре кемнәрне генә сокландырмас.* Сөембикә

**ФОТОСФЕ́РА** *и. гр. астр.* Кояшның металл парларыннан һәм газлардан гыйбарәт, яктылык һәм җылы бирә торган тышкы катлавы

**ФОТОТАСМА** *и.* Фотоаппарат ярдәмендә объектның кире (негатив) сурәтен чагылдырып алып кала торган, яктылыкка сизгер тасма. *Татарстанның иң әһәмиятле промышленность тармаклары булып нефть, химия, фототасма, фотожелатин, машина төзү, җиңел промышленность тармаклары санала.* Кызыклы география

**ФОТОТЕ́КА** *и. гр.* Фоторәсемнәр һәм аларның негативлары җыелмасы; алар саклана торган архив

**ФОТОТЕЛЕГРА́ММА** *и. гр.* Факс аша тапшырылган фоторәсем

**ФОТОТЕЛЕГРАФ** *и. гр.* Сурәтне еракка тапшыру җайланмасы

**ФОТОТЕЛЕГРАФИ́Я** *и. гр.* Сурәтне еракка тапшыру ысулы һәм эше. *Фотоэлементларның иң мөһим кулланыла торган өлкәләре – фототелеграфия, телевидение һәм тавышлы кино.* Физика курсы

**ФОТОТЕРАПИ́Я** *и. гр. мед.* Яктылык белән дәвалау

**ФОТОТИ́ПИК** *с.* Фототипия юлы белән эшләнгән

**ФОТОТИ́ПИЯ** *и. гр.* 1) Яктылыкка бик нык сизгер матдәләр (мәс., желатин) ярдәмендә пыялага яки металл пластинкага төшерелгән фоторәсемнең күчермәсен алу

2) Шул ысул белән алынган оттиск

**ФОТОТОВАР** *и. рус* Сатудагы фотография кирәк-яраклары

**ФОТОФО́БИЯ** *и. гр. мед.* Яктылыктан курку авыруы

**ФОТОХӘБӘРЧЕ** *и. к.* **фотокорреспондент**. *Ун минуттан редакция машинасы, Саттаров һәм фотохәбәрчене алып, Ык буена юнәлде.* Ф.Садриев. *Авыл аша узып киткән фотохәбәрче, гади бер кызыксыну белән, аның дәү апасы йортын төшереп алган ---.* Р.Мөхәммәдиев

**ФОТОХРО́НИКА** *и. гр.* Вакыйгаларның эзлекле рәвештә фоторәсемнәр белән бирелеше

**ФОТОЭЛЕ́КТРИК** *с. физ.* Яктылык энергиясенең турыдан-туры электр энергиясенә әверелү процессы белән бәйләнешле

**ФОТОЭЛЕКТРОН** *и. гр. физ.* Яктылык энергиясе тәэсирендә җисемнән бүленеп чыккан электрон

**ФОТОЭЛЕМЕНТ** *и. гр.-лат. физ.* Яктылык энергиясен электр энергиясенә әверелдерә торган прибор. *Фотоэлемент тоташтырылган электр чылбырында, фотоэлемент катодының ничек яктыртылуына карап, төрлечә ток хасил була.* Физика курсы

**ФОТОЭФФЕКТ** *и. гр.-лат. физ.* Яктылык энергиясенең электр энергиясенә турыдан-туры әверелүе күренеше. *Фотоэффект кебек күренешләрдә яктылык агышы үзенә бертөрле кисәкчекләр – фотоннар агышы кебек була.* Физика курсы

**ФӨКАРА** *җый. и. гар.* **1.** Фәкыйрьләр, ярлы-ябага. *Безнең бу кечкенә генә кәрван элек каланың читендәге фөкара кварталыннан үтте.* Г.Гобәйдуллин. *«Мөхәммәдия»нең төп классларына өстәмә рәвештә, мәчетнең беренче катындагы ике бүлмәсендә, ярлы һәм ятим балалар өчен башлангыч фөкара мәктәбе яшәде.* Р.Әмирхан

**2.** *с. мәгъ.* Фәкыйрь, ярлы, мохтаҗ булган. *Сүз чыкканда шуны да хәбәр бирим: Галиәкбәр агайның дәүләтенә караганда, һәр ел ун-унбиш мең тәңкә зәкят чыкса да, фөкара халык бу зәкяттән күп файдалана алмый торган иде.* Ш.Мөхәммәдев

**ФӨРЬЯД** *и. фар.* 1) Акыру, ярдәм сорап кычкыру, кычкырып елау. *Ат башыннан тоткан ул, Шүрәлене белми дә, ул моның фөрьядларын аслан колакка элми дә.* Г.Тукай

2) Зар, шикаять, моң-зар. *Шунда уйларсың, бу шагыйрь бушка аһ ормый, диеп: аһлары, фөрьядлары чынлап та урынлы, диеп.* Г.Тукай. *Ишет милләтнең ул фөрьяд вә зарын.* Дәрдемәнд

◊ **Фөрьяд ору** Зарлану. *Торып, фөрьяд орып, чүлләргә талды.* Дәрдемәнд

**ФӨРЬЯД ИТҮ** *ф.* Каты кычкыру, бакыру. *Шүрәле фөрьяд итәдер, аудан ычкынмак була.* Г.Тукай

**ФӨТҮВӘТ** *и. гар. иск.* 1) Яшьлек, егет чак, үсмерлек

2) Батырлык, кыюлык, егетлек, ирлек. *Абыстайларга җитсә төндә куәт, менә гайрәт! Менә һиммәт! Фөтүвәт!* Г.Тукай

**ФРАГМЕНТ** *и. лат.* 1) Әдәбият яки сәнгать әсәреннән өзек. *«Гасырлар һәм минутлар» поэмасы да, «Киләчәккә хатлар»ы да аерым фрагментлардан, әмма гомуми бер идея белән берләштерелгән кисәкләрдән тора.* Казан утлары

2) Нинди дә булса әһәмияткә ия язманың ертылып аерылган кисәге. *Шәҗәрәдән фрагментлар Р.Фәхреддиновның «Асар» хезмәтендә очрыйлар.* М.Әхмәтҗанов

3) Тарихи, борынгы сәнгать әсәрләренең сакланып калган ватыгы, кисәге

**ФРАГМЕНТАР** *с.* 1) Фрагментлардан торган, фрагментларда сакланган

2) *күч.* Өзек-өзек, аннан-моннан, ярым-ярты. *Күпләр вак күренешләр, артык әһәмиятсез кичерешләр һәм фрагментар фикерләр белән мавыкканда, мондый бербөтенлек тойгысы укучыга бик кадерле иде.* М.Вәлиев

**ФРАГМЕНТАРЛЫК** *и.* Фрагментар булу, кыска-кыска өзекләрдән тору, тулы булмау. *Пьесага беркадәр фрагментарлык хас, әмма ул автор тарафыннан махсус шулай эшләнгән булса кирәк, Г.Камалның «Безнең шәһәрнең серләре» комедиясендәге кебек.* А.Әхмәдуллин. *Хәзер, тирәнгәрәк карасак, бүгенге поэзиядә фрагментарлык көчәюенең сәбәбе – әдәбиятта рухи хәрәкәтнең сүлпәнәюеннән, фикер полюслары арасындагы киеренкелек йомшарудан икәнен чамаларга була.* Ф.Зөлкарнәев

**ФРА́ЕР** *и. нем.* 1) Купшы, көяз кеше. *Кара әле бу фраерга, чаңгыда ничек элдертә.* З.Фәтхетдинов. *Озын егет аңа: – Син, фраер, бар, шухерда тор! – дип ямьсез итеп эндәште.* Р.Кәрами

2) *жарг.* Җинаятьче күзлегеннән караганда, җинаять дөньясында очраклы кеше. *Унбиш ел төрмә сәндерәсендә ятып чыккан Губачевка ниндидер фраерның арага кысылуы ошамый.* Безнең гәҗит

**ФРА́ЗА** *и. гр.* 1) Тәмамланган мәгънәле фикерне белдергән гыйбарә, җөмлә, җөмләләр тезмәсе. *Һ.Такташның «Никахсызлар» шигырендә «Без – икәү, динсез, никахсыз – бер өйдә» дигән фразасындагы «икәү»дән әнә шундый исемлек төшенчәсе төсмерләнә.* Л.Җәләй. *Ни өчен бу фразада «яхшы» диюгә караганда, «начар» дип ешрак әйтәләр?* Кызыклы психология

2) Сөйләмне купшыландыру максатында кулланыла торган буш, күперенке, мәгънәсез сүзтезмә, гыйбарә. *Бу китерелгән юлларда нинди шигърият бар? Болар бит шалтыравыклы коры фразалар.* Ш.Маннур. *Ничек җавап бирергә дә белмәде, мондый очракта әйтә торган таныш фразадан башка әйбер уйлап таба алмады.* Ф.Садриев

3) Музыкаль әсәрнең зур булмаган һәм якынча тәмамланган өлеше. *Натураль минорга корылган бу көйнең һәр фразасында икешәр мотив.* Х.Курбатов

**ФРАЗЕОЛОГИЗМ** *и. гр. лингв.* Мәгънәсе үзенең составына кергән сүзләргә туры килми торган тотрыклы тәгъбир, сүзтезмә, әйтем; идиома. *Кайбер фразеологизмнардагы сүзләрнең аерым-аерым мәгънәләре белән шул әйтем белдерә торган мәгънә арасында бернинди эчке бәйләнеш булмый.* Н.Исәнбәт

**ФРАЗЕОЛО́ГИК** *с. лингв.* Фразеологиягә караган, фразеологиягә бәйле. *Кушма сүзләр, фразеологик берәмлекләрдән аермалы буларак, мөстәкыйль сүзләрдән гыйбарәт булмыйча, нигез морфемадан торалар.* Татар грамматикасы. *Тәрҗемә иткәндә, мәсәлән, ике мәгънәдә кулланылган әйтемнәр, ягъни фразеологик омонимнар күренешен дә искә алырга кирәк булачак.* Казан утлары

**ФРАЗЕОЛО́ГИЯ** *и. гр.* 1) Тел белеменең фразеологизмнарны өйрәнә торган бүлеге. *Хәзерге көндә татар лексикологиясе төрле юнәлештә шактый җентекле өйрәнелде, аның үзенең фразеология, ономастика дигән мөстәкыйль бүлекләре үсеп чыкты.* Татар грамматикасы

2) Фразеологизмнар җыелмасы. *Фразеология үзенең мәгънәсе, төзелеше һәм функциональ үзенчәлекләре ягыннан аерым сүзләрдән һәм гади сүз тезмәләреннән аерылып тора.* Н.Исәнбәт. *Татар теле фразеологиясе*

**ФРАЗЁР** *и. рус* Буш, эчтәлексез, купшы, әзер фразалар кулланучы кеше. *Кайберләре чын-чынлап фразёрлар: шәп сүз, акыллы сүз әйтәләр – көнләшеп укыйсың.* М.Мәһдиев

**ФРАК** *и. фр.* Арткы чабулары озын, алгысы кыска итеп тегелгән, гәүдәгә сыланып торган рәсми бәйрәм костюмы. *--- ак нейлон күлмәк, кара фрак – нәкъ менә халык артисты, мәшһүр дирижёр инде.* М.Мәһдиев. *Карт музыкант, урынына утырыр алдыннан, фрак итәкләрен күтәреп куйды.* М.Юныс

**ФРАКЦИОН** I *с. фр. сәяси* Фракцияләргә бүленгән, төркемнәргә таркалган; фракцияләр арасында барган. *Квартираларга качып, чәй эчә-эчә утырган фракцион киңәшмәләрегездә нинди карарлар кабул иттегез, шуны сөйлә.* И.Гази

**ФРАКЦИОН** II *с. фр. хим.* **1.** Өлешләп аерып алынган, өлешләрдән торган. *Фракцион состав*

**2.** *рәв. мәгъ.* Өлешләргә аерып, өлешләп. *Фракцион куу*

**ФРАКЦИОНЕР** *и. к.* **фракцияче**

**ФРА́КЦИЯ** I *и. фр. сәяси* Аерым партия, парламент, җәмәгать оешмасы әгъзаларының бер карашта торган группасы, бер партия эчендәге аерым группировка. *Думадагы мөселман фракциясен җиңгәнче сугышамыз, дип ант бирүен бу хатларга ничек ялгарга?* К.Нәҗми. *Корылтайда милли көчләр белән совет яклыларның кискен каршылыгы беренчеләрне үз фракцияләрен төзергә этәрә.* А.Хәбетдинов

**ФРА́КЦИЯ** II *и. фр. махс.* Газ хәлендәге яки сыек кушылманың өлешләп куу юлы белән аерып алынган өлеше

**ФРА́КЦИЯЛӘҮ** *ф.* Фракцияләргә бүлү, өлешләп аерып куу. *Үзәк газ фракцияләү җайланмасы сафка басып, беренче продукциясен бирде.* Мирас

**ФРА́КЦИЯЧЕ** *и.* Аерым фракция (I) вәкиле

**ФРА́КЦИЯЧЕЛЕК** *и.* Фракцияләргә бүлгәләнгән булу, сәяси таркаулык

**ФРАНК** I *и. фр.* Төрле чорларда төрле дәүләтләрдә, хәзерге вакытта Франция, Бельгия, Люксембург, Швейцария һ.б. илләрдә әйләнештә булган акча берәмлеге. *«Казанский телеграф» газетасында басылган отчётка караганда, 1913 елда ширкәтнең саф табышы 560 мең франк тәшкил иткән.* Р.Мостафин. *Франция франклары монда шул килеш, алмаштырмыйча йөри.* С.Сөләйманова

**ФРАНК** II *и. фр. тар.* 1) Безнең эраның башында Галлиядә, хәзерге Франция территориясендә яшәгән герман кабиләләренең бер группасы һәм шул кабилә вәкиле. *Франклар язуны борынгы римлылардан алганнар, һәм аларда латин телендә язылган әсәрләр таралган.* Татар әдәбияты тарихы. *Германнарның яулап алулары нәтиҗәсендә Франк дәүләте оеша, моңа аларның франклар дип аталган кабиләсе исем бирә.* Кызыклар дөньясында

2) *иск.* Европа кешесе, Көнбатыш культурасына караган кеше. *Ярты алә франк, ярты алә татар киенгән --- Касыйм мөселманнары.* Ш.Мөхәммәдев. *Франк табибын табарга һәм хансарайга алып килергә.* М.Хәбибуллин

**ФРА́НКЛЫК** *с.* Күпмедер франктан (I) торган, билгеле франк бәясендәге. *1680 елның 13 августында конкистадорлар талап җыйган 5,5 миллиард франклык алтынны трюмнарына төяп, Испаниягә кайтып килүче «Санта-Крус» исемле кораб әле һаман --- су астында ята.* М.Юныс

**ФРАНТ** *и. пол.* Көяз, купшы кеше. *Ул хәзер әнә нинди франт, нәкъ сиңа ярдәмче булырлык, «интеллигент».* Р.Мирхәйдәров. *Мондый киемнәрдән Ишкәй чын франт булачак.* Т.Әйди

**ФРАНЦУЖЕНКА** *и. рус* Француз милләтеннән булган хатын-кыз. *Әһә, актан киенгән, егерме-егерме бишләр тирәсендәге, зифа буйлы, сылу гәүдәле, ачык йөзле, төз борынлы француженка икән.* К.Миңнебаев

**ФРАНЦУЗ** *и.* **1.** Телләре роман телләре семьясына караган, католик динен тота торган, Франциядә яшәүче төп халык атамасы (үзатамалары – *франсе*) һәм шул халыкның бер кешесе. *Французлар – биредә бик күптәннән яшәүче галларның (кельтларның) безнең эраның IV–VI гасырларында көнчыгыштан басып кергән герман кабиләләре белән катнашуыннан килеп чыккан халык.* Чит илләрнең экономик географиясе

**2.** *с. мәгъ.* Французларга караган, французларныкы кебек. *Вәлишиннәр фабрикасы тыкрыгыннан чабып килүче француз яулыклы, ундүрт-унбиш яшәрлек кыз күренде.* К.Нәҗми. *Менә бик әйбәт француз яулык, бәясе дә арзан.* А.Гыйләҗев

**ФРАНЦУ́ЗЧА** *рәв.* **1.** Французларга хас итеп, французларда булганча, француз телендә. *Анда французча, немецча, инглизчә, эсперанточа язылган китаплар күп, дип карасалар да, хәзрәт һаман бирешмәде.* Ф.Әмирхан

**2.** *с. мәгъ.* Французларга хас булган, французларда булган; француз телендә. *Бервакыт без Митя белән циркка бик еш йөри башладык, анда җәлеп иткән нәрсә – французча көрәш булды.* А.Расих. *А.С. Пушкин җиде-сигез яшьлек малай чагында французча шигырьләр һәм хәтта эпиграммалар язган.* Кызыклы психология

**ФРАНЧА́ЙЗЕР** *и. ингл.* Франчайзинг нигезендә лицензия сатучы фирма

**ФРАНЧАЙЗИАТ** *и. ингл.* Танылган фирмадан аның сәүдә маркасын, бизнес моделен һ.б.ш. куллануга рәсми лицензия сатып алган кечерәк фирма

**ФРАНЧА́ЙЗИНГ** *и. ингл.* Базар икътисады субъектлары арасында зур фирмаларның яңа төзелгән фирмаларга үзләренең сәүдә маркасын, бизнес моделен куллану хокукын сатып бирүдән гыйбарәт мөнәсәбәт формасы

**ФРАНШИ́ЗА** *и. фр.* Бер фирма тарафыннан махсус шартнамә нигезендә икенче фирмага вакытлыча бирелә торган бизнес системасы; шуны куллану хокукын бирә торган шартнамә үзе. *Франшиза сатып алган эшмәкәрләр әлеге шәһәрләрдә «Түбәтәй»нең ризыкларын сату урынын 10–15 кә кадәр җиткерергә җыеналар.* Шәһри Казан

**ФРАХТ** *и. нем. махс.* Су юлы белән йөк ташыган һәм пассажирлар йөрткән өчен түләү; шул йөкне алып бару; шул турыдагы килешү. *Шулай ук фрахт шартнамәсе, һәр пассажир белән хезмәт күрсәтү турында килешү дә таләп ителә.* Безнең гәҗит

**ФРАХТО́ВЩИК** *и. рус махс.* Йөк ташу бурычын үз өстенә алган кеше яки оешма, суднолар хуҗасы

**ФРӘНК** *и. иск. сөйл. к.* **франк** II (*2 мәгъ.*). *Монда, шиксез, французлар белән Рәсәй арасындагы каршылык күздә тотыла, юкса фрәнкләр үткен кылычы белән күпләрне кисүен телгә алмас та иде.* Ф.Яхин

**ФРЕГАТ** I *и. лат.* 1) *тар.* Өч мачталы элекке сугыш корабле. *Әдип [Радищев] ул чагында әле мул сулы булган Болакны, Болактагы пристаньны, әрле-бирле йөзгән төрле-төрле көймәләрне тасвирлый, Бишбалтада төзелгән фрегатны суга төшерү турында яза.* Р.Мостафин. *Британия корветлары һәм фрегатлары аны һич кенә дә тота алмый.* Кызыклар дөньясында

2) Хәрби диңгез флотында атом су асты көймәләренә каршы тору, авианосецларны саклау кораблары классы

**ФРЕГАТ** II *и. ит. зоол.* Аерым семьялык тәшкил иткән озын койрыклы зур кара диңгез кошы. *Болытлар янында ук биектә-биектә, гайрәтле, мәгърур, канатларын җилпемичә генә, бер фрегат оча.* Н.Хәсәнов

**ФРЕЗА** *и. фр. махс.* 1) Агач, металл һ.б.ш. каты материалларның өстен кыру, фигуралы ую өчен күппочмаклы кискеч корал

2) Җир йомшарту, торф кисү һ.б.ш. өчен әйләнеп торган пычаклары булган эш машинасы. *Аннан, кашыклы фрезаның эзе дә бүтәнчәрәк: кавынсыман һәм зуррак.* Р.Мостафин

**ФРЕ́ЗЕР** *и. к.* **фреза**. *Аның каршында ышкылау, фрезер станоклары тора.* А.Расих. *Ринат фрезер участогына таба атлады.* Н.Хәсәнов

**ФРЕ́ЗЕРЛАУ** *ф. махс.* 1) Фреза (*1 мәгъ.*) белән эшкәртү

2) Фреза (*2 мәгъ.*) белән йомшарту, кисү һ.б.

**ФРЕЗЕРО́ВКАЛАУ** *ф. к.* **фрезерлау** (*1 мәгъ.*)

**ФРЕ́ЗЕРЧЫ** *и.* Фрезер станогында эшләүче белгеч. *Тәбәнәк буйлы, чандыр гәүдәле фрезерчы Бәһрам, кемнеңдер күтәртмә баскычына килеп басуын сизеп, артына борылып карады, мастеры икәнен күргәч, карашын кире эшкәрткән деталенә юнәлтте.* Н.Хәсәнов. *– Башка фрезерчыларны да бу эшкә тартырга иде, – диде баш инженер төксе генә.* Ф.Абдуллин

**ФРЕЙДИЗМ** *и. инг.* Кешенең психик һәм иҗтимагый тормышын фәкать биологик инстинктлар, теләкләр билгеләли, дип аңлаткан агым (Австрия психиатры Фрейд исеменнән). *Фрейдизм сиңа да йоктымы? Әгәр хатының чибәр булмаса, мин сиңа ышаныр идем.* А.Гыйләҗев

**ФРЕЙДИСТ** *и. рус* Фрейдизм тарафдары

**ФРЕ́ЙЛИНА** *и. нем.* Көнбатышта монархия хөкем сөргән илләрдә патша, король хатыннарының, принцессаларның күңелен ачу өчен сарайда яшәп хезмәт итүче аксөяк нәселдән булган хатын-кыз. *Аны үзен королева Викториянең фрейлинасы дип алдашканы өчен кыйнаганнар.* Кызыклы психология

**ФРЕНО́ЛОГ** *и. гр.* Френология белән шөгыльләнүче галим

**ФРЕНОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Кешенең әхлак һәм психик сыйфатларын аның баш сөяге формасына карап белеп була, дип өйрәтә торган тәгълимат. *Кеше язмышын баш сөягенең калкулыгы, иңкүлекләреннән өйрәнү френология дип атала.* С.Шәрипова. *Фән тарихына Галль, баш сөяге конфигурациясе буенча кешенең характеры турында фикер йөртеп була, дигән тәгълиматны – френологияне тудыручы буларак кереп калды.* Могҗизалар энциклопедиясе

**ФРЕНЧ** *и.* Махсус өлге белән тегелгән, тышкы ягында зур-зур дүрт кесәсе булган хәрби куртка (инглиз фельдмаршалы исеменнән). *Полк командиры Кириченко, френч якаларын чишеп җибәргән хәлдә, өстәлгә җәелгән картага караган килеш уйланып утыра иде.* Г.Бәширов. *Өстендә тар погонлы, яшькелт соры френч, аякларында – краги белән кара ботинкалар.* Ә.Еники

**ФРЕ́СКА** *и. ит.* Дымлы штукатуркага суга изелгән буяу белән бизәк төшерү техникасы һәм шулай төшерелгән бизәк. *Критлыларның фреска, ваза һәм статуэткалардагы сурәтләренә һәм бигрәк тә төрбәләрдәге алтын маскаларга игътибар итик.* Ә.Кәримуллин. *Фреска – борынгы рәсем сәнгате*

**ФРИГИДЛЫК** *и.* Хатын-кызларда җенси салкынлык. *Олырак яшьтә исә ул [йокысызлык һәм ярсучанлык] импотенция һәм фригидлыкка китерә.* Сөембикә

**ФРИЗ** I *и. фр.* Стена, идән, түшәм, келәм һ.б. читендәге бизәкләп ясалган кайма

**ФРИЗ** II *и. фр.* Байкасыман төкле калын материя

**ФРИКАДЕ́ЛЬКА** *и. нем.* Тапалган иттән, балыктан ясалган түгәрәк чумар. *Ашка иттән яки балык итеннән фрикаделькалар ясап яки тарткан итне түгәрәкләмичә генә салырга мөмкин.* Йорт эшләре

**ФРИКАДЕ́ЛЬКАЛЫ** *с.* Фрикаделька салынган

**ФРИКАТИВ** *с. лат. лингв.* Авазларны әйткәндә һава агымы тарайган урын аша үтеп, өрелеп әйтелә торган; өрелмәле. *Фрикатив тартыклар ясалганда, сөйләм аппаратының берәр урынында тарайган урын, ярык була; һава агымы шул ярыкның стеналарына ышкылып үткәндә, турбулентлы һава өермәсе нәтиҗәсендә аваз барлыкка килә.* Татар грамматикасы

**ФРИСТАЙЛ** *и. ингл. спорт* Чаңгыларда фигуралы шуу, трамплиннан акробатик хәрәкәтләр ясап сикерү һәм таулы трассадан зур тизлек белән чаңгыда шуудан гыйбарәт спорт төре. *Иң күп медальләр тимераякта һәм чаңгыда узышу, биатлон, таудан чаңгыда шуу, сноуборд һәм фристайл төрләрендә җиңүчеләргә бирeләчәк.* Татарстан яшьләре

**ФРИЦ** *и.* Немец милләтендәге фашист (немецлардагы Фридрих исеменең кечерәйтү формасыннан). *Бер фрицка ике пуля болай да күп инде ул.* Г.Бәширов. *Мин очкан бөркет штурмовик фрицларның котын ала.* Р.Вәлиев

**ФРОНТ** *и. нем. хәрби* 1) Шеренгаларга тезелгән хәрби строй алды. *Взводны командирга фронты белән тезү*

2) Сугыш хәрәкәтләре кырында урнашкан сугышчан хәрби көчләрнең дошманга йөз белән торган ягы. *Иптәш лейтенант, алар фронт аша ничек чыга алырлар икән соң?* Г.Бәширов. *Фронтка таба юл тотарга, төп көчләр урнашкан якка чыгарга кирәк.* Г.Нәбиуллин

3) Бер командующий җитәкләгән хәрәкәттәге берничә армия берләшмәсе. *Көзгә таба армиянең бер өлешен Врангель фронтына күчерә башлаганнар.* Г.Бәширов. *Шулай итеп, Байкал арты фронтының 36 нчы армиясе 124 нче аерым сапёр батальоны солдатлары --- бер-берсен таптылар.* Г.Ахунов

4) Сугыш хәрәкәтләре барган, армия урнашкан район. *Фронттагы уллары дошманны тизрәк җиңсен өчен, кич утырып яңа кораллар эшлиләр.* Г.Бәширов. *Габдулла Рәсүлев Истанбулдан илгә кайтып төшү белән солдатка алына һәм фронтка китеп юкка чыга.* А.Расих

5) *күч.* Күмәк хәрәкәт, эшчәнлек өлкәсе, хезмәт итү даирәсе. *Хезмәт фронтында җиңеп чыгу шатлыгы белән канатланганбыз.* М.Әмир. *Көн саен Татарстан игенчеләре урак фронтында кызу көрәштә.* Татарстан яшьләре

6) *күч.* Иҗтимагый көчләр берләшмәсе. *Яшьләр фронты*

◊ **Фронт сызыгы** Сугыш хәрәкәтләре барган, дошман гаскәрләр берберсенә йөз белән торган ара. *[Санчасть] Аларны урап узган алманнар күзенә күренмәскә омтылып, фронт сызыгын куып җитәргә тырышты.* Т.Әйди. *Аның алдында – окоплар, траншеялар белән ергаланган, дотлар, дзотлар белән ныгытылган фронт сызыгы.* М.Насыйбуллин

**ФРОНТАЛЬ** *с.* 1) Фронт (*2 мәгъ.*) буйлап җәелдерелгән

2) *сәнг.* Йөзе белән тамашачыларга каратылган. *Әлеге әсәрдәге фотога төшү мотивы табылу һәрьяктан камил, төгәлләнгән фронталь композиция төзүгә ярдәм итә.* Казан утлары

3) Бер үк вакытта, тоташтан, бөтен кеше өчен башкарылган, берьюлы эшләнгән, гомуми. *Мәктәптә уздырылган фронталь тикшерү нәтиҗәләре буенча педсовет утырышы булды.* Мәгърифәт

**ФРОНТИСПИС** *и. фр. махс.* Китап титулының сул өлешендә урнаштырыла торган рәсем; сәрләүхә

**ФРОНТИТ** *и. лат. мед.* Маңгай куышлыгындагы лайлалы тышчаның ялкынсынуы

**ФРОНТОВИК** *и. рус* Фронтта булган, сугышта катнашкан кеше. *Фронтовик Хөсәен Шәрәпшин өенә кичләтеп кенә колхоз председателе үзе килеп керде.* Ә.Гайнуллин. *Ел саен Җиңү көнен бәйрәм иткәндә, фронтовикларны тантанага чакыралар, бүләкләр өләшәләр.* Сөембикә

**ФРОНТОН** *и. фр. архит.* Бинаның түбә кыеклары белән кәрнизе арасындагы өчпочмакланып торган өлеше һәм ишек, тәрәзә өсләрендәге шуңа охшаган бизәк. *Бу сарай үзенең фронтоннары һәм колоннадалары белән безнең Казан университеты фасадын хәтерләтә.* Г.Гобәй. *Хабаровск вокзалының фронтонында өч уклы сәгать күреп хәйран калдым.* М.Мәһдиев

**ФРОНТТАШ** *и.* Бер-беренә карата: фронтта бергә булган кешеләр. *Һәр елны фронтташларым янына барам.* Р.Мөхәммәтҗанов. *Хәлиуллин фронтташ дустын гаиләсе белән үзләренә кунакка алып китә.* Г.Ахунов

**ФРОНТЧЫ** *и. сир. к.* **фронтовик**. *Мин, кызыл фронтчы, инвалид, ни эшләп аның бүлмәсенә өстерәлим инде.* Г.Ибраһимов

**ФРУКТО́ЗА** *и. лат.* Балда, җимешләрдә, үсемлекләрдә була торган җиләк-җимеш шикәре. *Топинамбур – җир грушасы бүлбеләрендә инсулин, фруктоза, микроэлементлар бар.* Мөселман календаре. *Глюкоза күп булган нектардан ясалган бал тизрәк ката, нектарда фруктоза күбрәк булса – әкренрәк кристаллаша.* Бакчачы, яшелчәче һәм умартачы календаре

**ФТИЗИА́ТОР** *и. гр. махс.* Үпкә авыруларын дәвалаучы табиб, врач. *1995 елдан Татарстан фтизиатторлары һәм пульмонологлары ассоциациясе рәисе профессор А.А. Визель була.* Фәнни Татарстан

**ФТИЗИАТРИ́Я** *и. гр. махс.* Медицинада үпкә авыруларын һәм аны дәвалау юлларын өйрәнә торган фән. *1958 елда туберкулёзга каршы шәһәр диспансеры (ТПТД) оештырыла, ул да ГИДУВның фтизиатрия кафедрасының клиник базасы булып китә.* Фәнни Татарстан

**ФТОР** *и. гр. махс.* Химик элемент, ачы исле, аксыл сары төстәге агулы газ. *Фтор исә пешкән бәрәңгедә, карабодайда бар.* Безнең гәҗит. *Мәсәлән, диңгез балыкларында, йод һәм бромнан кала, фосфор, калий, магний, натрий, күкерт, фтор, бакыр, тимер, цинк, марганец, кобальт, молибден бар.* Идел

**ФУ** *ы.* 1) Ачулануны, ризасызлыкны, шелтәне белдерә. *– Фу, яңгыр нигә кирәк булды инде, елгада болай да су күп ич, – диде Таҗи.* А.Алиш. *Фу, каян әйттем әле сезгә, берәр кечкенә фельетон оештырып та, чыгарып та куярсыз әле сез.* М.Фәйзи

2) Җирәнүне белдерә. *Капчыкны актара башлаганы, фу-у-у исе, дип, борынын җыера.* Р.Мирхәйдәров

3) Арыганлыкны, талчыгуны белдерә. *Фу! Бөтенләй тыным бетте, чабачаба эштән чыктым.* Ш.Камал. *Кайда, салыгыз, кызлар, кымызны, фу, фу, эт булдым.* М.Фәйзи

4) Җиңел сулауны, котылуга куануны белдерә. *Фу! Шулмы курыккан еланыгыз?* С.Әдһәмова

**ФУ́ГА** *и. ит. муз.* Әсәрне берничә тавышка бер-бер артлы кабатлаган, ягъни имитация принципларына нигезләнгән музыкаль форма. *Бахның фугасын да, Гендельның прелюдиясен дә, Шостаковичның «Урманнар турындагы җыр»ын яисә Рубинштейнның «Мелодия»сен дә бер үк төсле итеп игълан итәргә ярамый да ярамый.* Ш.Котдусова

**ФУГА́НОК** *и. нем. махс.* Агач такталарны тигезләп ышкылый торган эш коралы; озын ышкы. *[Ишекнең] --- линолеум кырган турын юнып алдым. Фуганок белән әйбәтләп тигезләдем.* Ф.Абдуллин

**ФУГАС** *и. фр.* Артиллерия снаряды, гомумән шартлаткыч матдә зарядының сөйләмдәге атамасы. *Чыбыклар тирәсе җир астына яшерелгән фугас, «бүре базлары» белән ныгытылган.* Ш.Усманов

**ФУГАСЛЫ** *с.* Газ тәэсирендә, бәрелү, ут кабыну нәтиҗәсендә кабатлап шартлый торган. *Камалыштагы 872 көн эчендә төньяктагы башкаланың һәр квадрат метр җире 16 фугаслы, 320 яндыра торган бомба һәм 480 артиллерия снаряды кабул итә.* Т.Нәҗмиев

**ФУЖЕР** *и. фр.* Озын аяклы зур бокал. *Әгәр инде яхшы грузин виносы булса, ул аны берәр фужер гына китертмичә калмый.* Ә.Еники. *Минераль һәм җиләк-җимеш суларына, ширбәтләргә 250 граммлы фужерлар куела.* Татар халык ашлары

**ФУК** *и. рус* Шашка уенында: уен барышында көндәшеңнең ялгышы яки отмыйча калдырганы өчен, тактадан фигурасын алу. *Андый гына күчереп кую ярый ла инде..., алай булса, фук итеп кенә ал!* К.Нәҗми

**ФУКС** *и. нем.* Бильярд уенында: очраклы отылган шар, көтелмәгән уңыш

**ФУКСИН** *и. нем.* Кызыл төстәге анилин буяу

**ФУ́КСИЯ** *и. лат. бот.* 1) Кырлыганчалар семьялыгыннан гадәттә ачык кызыл төстәге чәчәк ата торган Көньяк Америка үсемлеге

2) Көньяк өлкәләрдә бакча гөле буларак үстерелә торган декоратив төре; бүлмә гөле, тамчыгөл, алкагөл. *Фуксия --- яз башыннан алып көзнең соңгы көннәренә кадәр чәчәк ата.* Йорт эшләре

3) Шул чәчәк исеменнән алынган: кызыл төснең бер төсмере. --- *бүген исә кызгылт сары һәм фуксия төсе кушылмасы – сезонның иң зәвыклы төсе булып санала.* Сөембикә

**ФУЛЬГУРИТ** *и. лат.* Комлыкларны яшен сукканда, ком бөртекләренең яшен үткән эз буйлап эреп укмашуыннан барлыкка килгән, тармакланып киткән көпшәсыман озын таякчыклар. *Тауларда яшен зур-зур кыяларны җимерә, ә комлы урынга сукканда, комны эретеп, тармаклы көпшәсыман масса хасил итә, аны фульгурит, халык арасында шүрәле бармагы дип атап йөртәләр, кайбер фульгуритлар берәр метрдан да озынрак була.* М.Зиннәтов

**ФУЛЯР** *и. фр.* **1.** Юка, йомшак ефәк тукыма

**2.** *с. мәгъ.* Шул тукымадан тегелгән

**ФУНГИЦИД** *и. лат. махс.* Авыл хуҗалыгы үсемлекләрендә авыру китереп чыгарган гөмбәчекләргә һәм бактерияләргә каршы кулланыла торган матдә. *Үсемлек корткычларына һәм авыруларына каршы көрәштә кулланыла торган матдәләр --- ике группага бүленәләр: 1) инсектицидлар һәм 2) фунгицидлар.* Яшелчәчелек

**ФУНДА́МЕНТ** *и. лат.* 1) Корылманың таштан, бетоннан салынган нигезе. *Фундамент салу, колонналар күтәрү, арматурадан челтәр үрү – һәммәсен җентекләп аңлатты.* Х.Мөхәммәтшин. *Завод корпусларын төзегәндә, әтинең көче, сәләте бик тә ярап куя: ул бетоннан фундамент сала, гаять авыр эштә була.* К.Миңлебаев

2) *күч.* Нигез, таяныч, база. *Социализм фундаментының нык, җимерелмәс булып төзелүен күз алдына китерде.* А.Таһиров. *Җәмгыятьнең икътисади фундаменты. Фәнни фундамент*

**ФУНДАМЕНТАЛИЗМ** *и. лат.* Дини карашларны заманга яраклаштыруга, иске дини карашларны үзгәртүгә каршы теологик юнәлеш. *Аннан килеп, фундаментализм, пангарәпчелек – сәяси уен, халыкны буйсындырып тотуның бер алымы, чын демократияне кысу, буу чарасы.* Т.Галиуллин

**ФУНДАМЕНТАЛИСТ** *и. рус* Фундаментализм тарафдары. *Кайда берәр нәрсә шартласа, --- нәрсә генә җимерелсә дә --- шул ук мизгелдә фундаменталистларга, сөнниләргә я ваһһабиларга яла ягып куялар.* Мөселман календаре

**ФУНДАМЕНТАЛЬ** *с. лат.* 1) Төпле нигезле, тирән мәгънәле; әһәмиятле, җитди эчтәлекле. *Э.В. Севортянның фундаменталь хезмәтендә азәрбайҗан теленең билгеләргә мөмкин булган барлык фигыль ясаучы кушымчалары тикшерелә.* Татар грамматикасы

2) Баш, төп, үзәк. *Медицина фәненең алдагы үсеше электрон микроскопия, тамгалы радиоактив кушылмалар кулланып, фундаменталь биология һәм медицина проблемаларын тикшерүгә бәйле.* Фәнни Татарстан.

**ФУНДУК** *и. гр.* Каенчалар семьялыгыннан чыгышы белән Көньяк Европадан булган гади чикләвек куагының культуралаштырылган төре һәм аның чикләвеге. *«У-у, аларның алты төп йөзем! Аларның фундук агачы өч төп», – дип сөйләшәләр.* М.Мәһдиев. *Аерым районнарның авыл хуҗалыгында чикләвекләр – фундук, кузы чикләвекләре, миндаль, фисташка җыю һәм ефәкчелек әһәмиятле ярдәмче кәсепләр булып торалар.* Чит илләрнең икономик географиясе

**ФУНИКУЛЁР** *и. фр.* Тауга күтәрелү һәм төшү өчен корыч канатка беркетелгән тимер юл. *Руставели проспектына фуникулёрга утырып төшкән чагында, ул кинәт күптәнге очрашуны хәтерләп алды.* Р.Мирхәйдәров

**ФУНКЦИОНАЛЬ** *с.* 1) Функциягә мөнәсәбәтле, функциясенә, алып барган вазифасына бәйле. *Функциональ система*

2) Организмның һәм органнарның эшчәнлегенә бәйле. *Галимнәр организмның үзара бәйләнгән ике функциональ системасын – эндокрин һәм иммун системаларны өйрәнүгә тукталалар.* Могҗизалар энциклопедиясе. *Алар исә тикшерү вакытын киметәләр, кан тамырларын инвазив булмаган визуаль ысуллар кулланып, функциональ сурәт булдыру мөмкинлеге тудыралар.* Фәнни Татарстан

**ФУНКЦИОНЕР** *и. рус* Коры вазифа үтәүче, формаль эшчәнлек алып баручы дәүләт хезмәткәре. *Дьяков Иван Николаевич, система калыпка салган кешеләрнең күпчелегеннән аермалы буларак, катып калган функционер булып чыкмады, замана җилләренә сизгерлек күрсәтте: картлар китереп кыскач, Киләче авылында мәчет салуга ярдәм итү эшенә дә алынды.* Т.Галиуллин. *Эстетик фикерләүдә шул фирка функционерларыннан ерак китмәгән.* Ф.Галимуллин

**ФУ́НКЦИЯ** *и. лат.* 1) Эшчәнлек, вазифа, йөкләтелгән бурыч. *Дәүләтебез җитмеш ел дәвамында гаилә функциясен үз өстенә ала килде: укытты, тәрбияләде, дәвалады.* Сөембикә

2) *мат.* Үзгәреше икенче зурлык үзгәрешенә бәйле алмаш зурлык. *Координаталар методы функцияләрне график юл белән тикшерү һәм тигезләмәләрне график юл белән чишүдә киң кулланыла башлый.* Алгебра. *Функцияләр теориясе. Тригонометрик функция*

3) *махс.* Организмның яки аерым органның эшчәнлеге. *Аналогик органнар – күбәләк канаты, кош канатлары һәм ярканат канатлары: аларның функцияләре бер, һәм алар шушы функциягә ихтыяҗ туганлыктан барлыкка килгәннәр.* Кызыклы психология

4) *кит.* Берәр күренешкә бәйле рәвештә үзгәрүчән күренеш

5) Мәгънә, роль. *Акча функциясе*

**ФУНТ** *и. лат.* 1) Метрик системага кадәр кулланылган, Россиядә 409,5 граммга тигез булган авырлык үлчәү берәмлеге. *Мин шунда алтмыш сумга дүрт тюк ситсы, утыз фунт чәй алып калдым.* А.Таһиров. *Сергий Радонежский чиркәвендә җиде пот көмеш, биш фунт алтын, йөз сиксән алты энҗе бөртеге саклана.* З.Фәтхетдинов

2) Төрле илләрдә төрлечә кабул ителгән (Англиядә 453,6 граммга тигез булган) авырлык үлчәү берәмлеге. *Бредли янынннан узганда сугылып чыгыгыз әле, миңа бер фунт иң каты тәмәке җибәрсен.* К.Дойл

3) Төрле чорда төрле дәүләтләрдә әйләнештә булган акча берәмлеге

**ФУНТ-СТЕ́РЛИНГ** *и. ингл.* Англиядә төп акча берәмлеге. *Шул талап алган алтынның диңгезгә ыргытылган өлеше генә дә берничә миллиард фунт-стерлинг, дип билгелиләр экспертлар.* М.Юныс. *И-их, малайлар, минем шулхәтле әниле буласым килә. Чөнки Әни – заты берниндu долларлар, фунт-стерлинглар белән дә бәяли алмаслык олуг Бәхет ул!* А.Хәсәнов

**ФУ́РА** *и. нем.* 1) XX гасырга кадәр бик озын ат арбасы. *Бу авыр фураны олы юлда әллә ничә машина узып китәчәк әле.* А.Гыймадиев

2) Тягач һәм ярымприцеп яки прицептан торган автопоезд, бик озын йөк машинасы. *Озын арбалы машиналар – фураларның бозлавыклы, таулырак юл участокларында тоткарлыклар булдырмавын тәэмин итү мөһим.* Безнең гәҗит

**ФУРАЖ** *и. фр.* Терлек азыгы. *Хәдичәләр фуражын да, печәнен дә, башкасын да, әз булса да, алып кайтырга тырыштылар.* Ф.Садриев. *Яз көне фураж сорап теңкәмә тидең, ә хәзер төшереп биргән икмәктән дә йөз чөерәсеңме?* Х.Ибраһимов

**ФУРАЖИР** *и. фр.* 1) *иск.* Атлы гаскәр өчен фураж әзерләүче, табучы гаскәри

2) *к.* **фуражчы**. *Хуш исле печән йөгеп үз җаваплылыгына кабул итүче фуражир Салихҗан Касыймовның йөзе якты, күңеле күтәренке.* Якты юл

**ФУРА́ЖКА** *и. рус* Кырпулы, козырёклы баш киеме. *Фуражкасын салып янына куйды, пиджак төймәләрен чишеп җибәрде...* Г.Бәширов. *Ак төлке тиресеннән тегелгән кыска тун һәм купшы фуражка, биек үкчәле ак ботинка аны ифрат та чибәр күрсәтә иде.* Т.Әйди

**ФУРАЖЛЫК** *и.* **1.** Фуражга билгеләнгән бөртекле ашлык. --- *фуражлык кына рәтебез бар, тик ашатырга ярамый.* В.Нуруллин

**2.** *с. мәгъ.* Фуражга дип билгеләнгән. *Фуражлык иген*

**ФУРАЖЧЫ** *и.* Фураж хуҗалыгын алып баручы, фураж әзерләүче, саклаучы һәм таратучы. *Габдулла абзый, сөт кабул итү белән беррәттән, фуражчы да бит. Онны берәр соскы гына артык тамызса да, сыер эченә керә лә ул!* М.Хәсәнов. *Бервакыт, якын-тирәдә салам калмагач, фуражчы Әбүбәкер ага Якупов, бригада хатын-кызларын җыеп, Уркалыга, язгы өзеккә дип калдырган эскерткә алып китә.* М.Ибраһимов

**ФУРГОН** *и. фр.* Ябулы зур арба һәм ябык зур кузовлы йөк машинасы. *Камерадагы һәм фургондагы караңгыдан соң, түшәмдә пыяла чуклы кандил, өстәлендә киң филтәле лампа янып торган бүлмәгә кергәч, күзләре камашып китте аның.* К.Нәҗми. *Бригада штабы һәм сәяси бүлек елганы Краснокамск янында сай урында фургоннарда кичә.* Д.Шәрәфетдинов

**ФУРГОНЛЫ** *с.* Фургоны булган. *Ишек алдында брезент фургонлы автомашина тора.* Р.Вәлиев

**ФУ́РИЯ** *и. лат.* 1) Рим мифологиясендә үч алу алиһәсе

2) *күч.* Усал телле явыз хатын. *Инглиз теленең аңлатмалы сүзлегендә «тартар» сүзенең синонимы итеп «татар» сүзе дә бирелә һәм бу исем, халык этнонимы булу белән бергә, «кызып китүчән кеше», «мегера», «фурия» мәгънәсендә дә китерелә.* Ә.Кәримуллин

3) *зоол.* Австралиядә очрый торган зәһәр агулы елан

**ФУРКАН** *и. гар.* Коръән. *Мөхәррирсез төзелдеме бу Фуркан?* Г.Тукай

**ФУРМАН** *и. нем.* 1) *иск.* Озын агач арбада извозчик

2) *сөйл.* Озын агач арба, фура, ридван. *Элекке еллардагы шикелле арбаларга төялеп уракка китүләр, ындыр табакларына фурман тутырып көлтә ташулар бөтенләй булмады да...* Ә.Еники. *Кичләрен басудан авылга кайткач та дүртәр-бишәр ниргә көлтә төялгән фурманнардан аерылмый идек.* Г.Галиев

**ФУРНИТУ́РА** *и. фр. махс.* Һөнәрчелектә, җитештерүнең төрле тармакларында кулланыла торган ярдәмче материаллар (мәс., тегүдә – җеп, төймә, каптырма, тасмалар һ.б.). *Пыялапластик асбест полиэфир сумаласын, пыяла җепселләрен һәм онтасыман тутыргычларны пресслап та җитештерелә, аңардан тәрәзә һәм ишек блоклары, фурнитура, санитар-техник эшләнмәләр ясала.* Төзү материаллары

**ФУРУ́НКУЛ** *и. лат. мед.* Эренле чуан, сызлавык. *Балан җимешләренең төнәтмәсе шулай ук ашказаны һәм эчәклек җәрәхәтеннән, фурункуллардан, экземалы тиредәге җәрәхәтләрдән дә яхшы нәтиҗә бирә.* Мөселман календаре

**ФУРУНКУЛЁЗ** *и. лат. мед.* Берөзлексез чуан, сызлавык чыгып тору, тәнне чуан, сызлавык басу. *Фурункулёз, тире чабыру, бетчә чыгу матдәләр алмашы бозылудан килә.* Кәеф ничек? *Хроник фурункулёз*

**ФУРШЕТ** *и. фр.* Өстәлгә куелган салкын кабымлыклар һәм эчемлекләр белән аягөсте генә үткәрелә торган мәҗлес. *Алай гына да түгел, һәртөрле банкет, фуршет, бәйрәмнәргә чик куелачак.* Ватаным Татарстан

**ФУТ** *и. ингл.* Инглиз телле халыкларда, шулай ук метрик система кертелгәнче Россиядә уртача олы кеше табаны озынлыгына туры килгән борынгы озынлык үлчәү берәмлеге. *Мин тугыз фут чамасында ераклашкач, дүрт дюймга якын зурлыктагы икенче түгәрәк күрү мәйданыннан бөтенләй юкка чыкты.* Кызыклы психология

**ФУТБОЛ** *и. ингл.* Ике команданың каршы як капкасына мөмкин кадәр күбрәк туп тибеп кертүдән гыйбарәт спорт уены. *Очрашкандагы безнең төп уен хәзер – футбол тибү.* А.Расих. *--- малай гел балалар арасында кайнаша, әле футбол, әле волейбол --- уйный икән үзләре белән.* С.Сөләйманова

**ФУТБО́ЛКА** *и. рус* Кыска җиңле, кайтарма якалы яки якасыз, киҗемамык спорт күлмәге. *Яланбаш, коңгырт чәчләрен тузгытып, аркасына спорт сумкасы аскан, сары футболка кигән Фәезе күренмәде.* Н.Хәсәнов. *Гел күк төстәге футболка кия, һичьюгы шуннан танырсың, дигәннәр иде.* Ф.Җамалетдинова

**ФУТБОЛЧЫ** *и.* Футбол уйнаучы. *Футболчыларның майкаларына милли эмблема уелган.* И.Надиров. *Җәмил әллә кайчан мәктәп янындагы спорт мәйданында, тугызынчы класс футболчылары тренировкасында булырга тиеш иде.* А.Гыйләҗев

**ФУТЛЯР** *и. нем.* Кыйммәтле яки ватылучан әйберне саклау, салып йөртү тартмасы. *Минем скрипкадан тәмам гайрәтем чикте, һәм мин аны, футлярына салып, шкаф өстенә олактырдым.* А.Расих. *Май заводында әрҗә ясаучылардан тиз генә озын футляр сыман бер нәрсә эшләтеп алдым.* Ә.Еники

**ФУТУРИЗМ** *и. лат.* XX йөз башында әдәбиятта һәм сәнгатьтә иске иҗат алымнарына һәм традицияләренә каршы күтәрелгән, форманы эчтәлектән аерган, гадәттән тыш формаларны яңа иҗат стиленә әйләндерергә омтылган формалистик юнәлеш. *Озак еллар дәвамында тискәре яктан гына бәяләнеп килгән символизм, футуризм, акмеизм кебек модернистик алымнарның, шәкли тәҗрибәләрнең татар поэзиясенә ясаган тәэсирен фәнни бәяләү хаҗәте көн тәртибендә тора.* Т.Галиуллин. *Формаль дип йөртелгән футуризм, имажинизм юнәлешләренең барлыкка килүе, аларның билгеле бер рәвештә оешканлык алуы иҗади эзләнүләргә мөмкинлек булуы турында сөйли иде.* Ф.Галимуллин

**ФУТУРИСТ** I *и. рус* Футуристик әсәрләр иҗат итүче, футуризмны яклаучы кеше. *Гармун, дуслар, футурист түгел, ул – реалист.* Ф.Кәрим. *Футуристлардан бер төркем бу белдермәне ялганга чыгарырга теләде.* Х.Госман

**ФУТУРИСТ** II *с.* Футуристик карашларда торган, шул иҗат белән шөгыльләнгән. *Белмим, бу сезнең футурист художниклар, нәрсә уйлап, ул шарларны, почмакларны ясыйлар?* Һ.Такташ. *Футурист артистлар үзләре дә шул сәхнә геройларына охшарга тырышалар.* Ф.Галимуллин

**ФУТУРИ́СТИК** *с.* Футуризмга мөнәсәбәтле, футуризм стилендә иҗат ителгән, шул юнәлешне хуплаган. *Газета футуристик шигырьнең рифмасыз, чәчмә формада язылу мөмкинлеген генә искәртеп үтә.* Д.Заһидуллина

**ФУТУРИСТЛЫК** *и. к.* **футуризм**. *Такташ – тар индивидуалистсимволистлык, Кутуй – футуристлык, Нәҗми имажинистлык юлында кайбер тәҗрибә адымнар ясадылар.* Ф.Бурнаш. *Г.Кутуй футуристлык шигырьләренең төрле рәвештәгеләрен иҗат итүдә аеруча өлгерлек күрсәтте.* Ф.Галимуллин

**ФУТУРО́ЛОГ** *и. лат. неол.* Аерым билгеләрне (сәяси вазгыять, экология һ.б.ш.) анализлап, киләчәктә булырга мөмкин хәлләрне фаразлаучы галим; аналитик. *Кайбер футурологлар киләчәк заман кешесен гадәттән тыш зур һәм пеләш башлы итеп күз алдына китерәләр, күренекле фантаст һәм биолог Г.Уэллсның бер романында киләчәк заман баласы әзмәвердәй баһадир гәүдәле итеп сурәтләнә.* А.Тимергалин. *Футуролог фикеренчә, егерме еллап вакыт узганнан соң, фәннең үсеше кеше организмын кабаттан биологик программалау чарасын табу мөмкинлеге бирәчәк.* Ватаным Татарстан

**ФУТШТОК** *и. ингл.-нем. махс.* Фут таягы, елгаларда, күлләрдә суның тирәнлеген үлчи торган, ачык төстәге буяулар белән (м, см, фут, дюймнарга) бүлгәләнгән колга

**ФУФА́ЙКА** *и.* 1) Бәйләнгән җылы кием. *Бер почмакта иске күн диванда гырлап яткан шофёрның да колагына керде, ахрысы, бу сүз – сискәнеп башын күтәрде, фуфайка җиңе белән сыпырып, өстәлдәге берничә шахмат фигурасын идәнгә төшерде.* Х.Вәлиәхмәтов. *Әтисеннән калган йон фуфайкасын да үзе салды.* В.Нуруллин

2) Сырып тегелгән кыска җылы өс киеме. *Чаңгыларны да, фуфайканы да мичкә тыгып яндырдым.* Х.Вәлиәхмә-

тов. *Ул вакытта инде сырган фуфайкаларны уңайлы мех якалы кыска боброк пальтолар алыштырып бетергән.* Р.Мирхәйдәров

**ФУФЫЛДА́У** *ф.* Фу-фу дигән авазлар чыгару. *Кайдадыр ябалак фуфылдый.* Р.Батулла. *– Әйдә, алайса кой, Газизә, – диде Хафиз һәм, шәрә аркасына су тамганчы ук, фуфылдарга тотынды.* З.Вәли

**Фуфылдап алу** Аз гына, кыска вакыт фуфылдау. *Тагын бер кат мәче башлы ябалак фуфылдап алды. Аннан соң шаулегән мияулаганы ишетелде.* Казан утлары

**Фуфылдап кую** Бер тапкыр фуфылдаган аваз чыгару

**ФЫНДЫК** *и. гр. к.* **фундук**. *Иң калориялесе – фындык, аннан соң әстерхан, бразилия, бадәм чикләвекләре, кешью килә.* Мәдәни җомга. *Әйе, диңгез, кояш, йөзем, шәфталу, фындык чикләвеге, шифалы су һәм һава өчен тартышырга була, билгеле.* Ватаным Татарстан

**ФЫ́Р ИТҮ** *ф. к.* **фырлау**. --- *лапас күләгәсендә утырган Фирүзә фыр итеп күтәрелде, тырылдап өйгә кереп китте...* А.Гыйләҗев

**ФЫ́Р КИЛҮ** *ф. к.* **фырлау**. *Үзен таяк белән тукмаклап чыгарасы урында, мин сиңа әйтим, бу килмешәк, фыр килеп, усал фырылдап, мине куркытмакчы, түтәлдән кумакчы була.* А.Хәсәнов

**ФЫРЛА́У** *ф.* 1) Өзлексез җилпенгән, канат каккан тавыш чыгару, очып йөрү; һавага ышкылып, фырлаган тавыш чыгару. *Күбәләк тик ямь сөя, тик гөл янында фырлый ул.* Ш.Бабич. *Колак төбеннән генә, фырлап, пар кәрәшә очып узды.* Ф.Садриев

2) Ашыгу, ашкыну, очкан кебек фырлаган тавыш чыгару. *Аны-моны искәрмичә барам, башын чайкый-чайкый артымнан фырлап килгән Аманат кинәт җилкәмне умырып алды...* А.Гыйләҗев

3) *күч.* Ризасызлык белдереп мыгырданып йөрү

**Фырлап алу** Бераз, җиңелчә генә фырлау

**Фырлап җибәрү** Кинәт фырларга керешү

**Фырлап китү** Кинәт фырлый башлау

**Фырлап кую** Кыска гына, бер тапкыр фырлау

**Фырлап тору** Озак вакыт дәвамында фырлау; бертуктаусыз фырлау

**Фырлый башлау** Фырларга керешү

**ФЫРТ** *с.* **1.** Көяз, купшы («франт» сүзеннән фонетик үзгәргән форма). *Бу кыланышы аның кыз алырга барырга әзерләнгән фырт егетне хәтерләтә.* С.Поварисов. *Ишкәй чишенергә оялды, үзенең лепшердәгән, артык иркен иске трусигы белән шушындый фырт ханым янәшәсендә ничек аунасын инде ул?* Т.Әйди

**2.** *рәв. мәгъ.* Күзгә бәрелерлек итеп, көязләнеп, купшы итеп. *Тик бик фырт киенгән офицерлары гына сәүдәгәр өйләрендә граммофон уйнатып, күпец кызлары белән парлап биешеп, кәефсафа кылып йөрделәр.* Ә.Еники. *Андагы укучылар – барысы да диярлек фырт киенгән, шәһәрнең югары сферасыннан чыккан яшьләр.* А.Расих

◊ **Фырт кына** Ачуланып, үпкәләп, капыл гына. *Хатын фырт кына борылып кереп китте, кулындагы кершән савытын идәнгә атты, креслога егылып, улап ук еларга кереште.* А.Гыйләҗев

**ФЫРТЛАНУ** *ф.* Көязләнеп, купшыланып, һаваланып йөрү. *Ул да хатын-кыз тирәсендә фыртланырга бик ярата.* З.Фәтхетдинов

**Фыртланып алу** Бераз, аз гына фыртлану. *Кайры тунын чишеп җибәргән яшь егет бүреген кыңгырайтып фыртланып алды да сылу кыз каршына чыгып биеп китте.* Казан утлары

**Фыртланып йөрү** Гел, һәрвакыт көязләнгән, купшыланган хәлдә булу, һәрвакыт һавалы кылану

**ФЫРТЛЫК** *и.* Көязлек, купшылык; һавалылык. *[Рәшит абыйның] Түбәтәй киюе һич тә фыртлык билгесе түгел, башкалардан аерылып, күзгә бәрелеп тору өчен түгел.* М.Хуҗин

**ФЫРТЫНА** *и. ит. иск.* 1) Давыл, буран. *Монда быел кар фыртынасы, өч көннән бирле һич туктаусыз кар явадыр.* Ш.Мөхәммәдев

2) Диңгез давылы, шторм. *Диңгездә фыртына, пассажирлар, шул җөмләдән әниләр, укшыйлар, косалар, аларны рәхимсез рәвештә диңгез тота.* А.Расих

**ФЫ́Р-ФЫР** *иярт.* Җилпенүне, җилдә җилфердәүне, канат какканда чыккан тавышны белдерә. *Фыр-фыр очасың, ә эш һаман арта тора.* Ф.Садриев

**ФЫРЫЛДА́У** *ф. к.* **фырлау**. *Каяндыр шунда кыек буеннан гына нәрсәдер фырылдап күтәрелде.* Ә.Еники. *Өй кыекларына кунган күгәрченнәр фырылдап һавага күтәрелде.* З.Фәтхетдинов

**ФЫТЫР** *и. сөйл. к.* **фитыр**. *Коммуна әгъзалары арасында ураза тотучылар, Хәбирә карчыкка фытыр садакасы бирүчеләр байтак иде.* М.Мәһдиев

**ФЫ́ЧТ-ФЫЧТ** *иярт.* Һаваны ярып, сызгырып килеп бәрелгән пулялар тавышын белдерә. *Самолёт тагын очып килде, тагын фычт-фычт итте. Инде Хәлим бу фычт-фычтның үлем икәнлеген аңлый иде.* Г.Гобәй

**ФЬЕЛЬД** *и. норв.* Скандинавия ярымутравында чагыштырмача тигез түбәле, платалы таулар. *Алар кыя-таш ватыклары белән, үләнгә ярлы болыннар һәм кечкенә күлләр яки мүкле сазлыклар белән капланган биек тау фьельдларыннан гыйбарәт.* Чит илләрнең экономик географиясе

**ФЬОРД** *и. к.* **фиорд**. *Фьордларда күп төрле тюленьнәр, моржлар, тешле китлар, ак дельфиннар тереклек итә.* Кызыклы география

**ФЬЮ** *иярт.* 1) Һаваны ярып селтәнү, сызгыру тавышын белдерә. *– Фью-ю! – дип сызгырып җибәрде Янгураз.* Т.Әйди

2) *күч. гади с.* «Табан ялтыратты, тайды, шылды» мәгънәсен белдерә. *Фью, әллә кайчан җилләр исте инде аннан*

**ФЬЮТ** *иярт.* Кискен һәм кыска гына сызгырып кую тавышын белдерә; тфит. *Фьють, дип бер сызгырып, әйдә на-а, дип кычкырып җибәрүем булды минем, коточкыч көчле бүрем шүрләгән икән, факыр.* Х.Туфан

**ФЬЮ́ЧЕРС** *и. ингл.* Товарларны һәм кыйммәтле кәгазьләрне сатып алучыга килешү төзелгән вакыттагы бәя белән сатудан гыйбарәт килешү формасы. *Фьючерс базары. Фьючерс контракты*

**ФЮЗЕЛЯЖ** *и. фр.* Самолёт корпусы, каркасы. *Кояшның кыздыруы шул дәрәҗәдә иде ки, самолёт фюзеляжы янына якын килеп булмый.* М.Мәһдиев

**ФЮРЕР** *и. нем.* Фашистлар Германиясендә национал-социалистлар партиясе җитәкчесе А.Гитлерга мөрәҗәгать итү атамасы; юлбашчы. *Швециягә басып алырга хәтта фюрер үзе дә базмый бугай ич әле.* Т.Әйди. *Фюрерга каршы коткы таратуда гаепләп, Карлны хәрби трибунал судына бирәләр.* В.Нуруллин

# Х

**ХАВЫЗ** *и. гар.* Ясалма күл, бассейн, сулык; Көнчыгыш илләрендә шәһәр мәйданнарында, паркларда, бакчаларда яисә мәчетләр янында ясалып куелган ясалма сулык, эчә торган су резервуары. *Аның бер як кырыендагы таш улактан челтерәп су агып тора, хавызда исә төрле суүсемнәр чайкала, төбендәге төрле төстәге чуерташлар вак дулкыннар аркылы биеп торучы ниндидер җан ияләрен хәтерләтәләр.* Ф.Латыйфи. *Аннан соң ул тиз-тиз атлап мәчеткә керде, эчке ишегалдында картлар намазга әзерләнә, тут агачы күләгәсендә җиде карт тора, ә җиде намаз карты хавызда комганнарына су тутыра.* Р.Мирхәйдәров

**ХАДИМ** *и. гар.* 1) Хезмәтче, ялчы. *Табиб белән хадимнән башка аның бусагасын атна буе берәү дә атлап кермәде.* М.Әмирханов

2) Хезмәткәр, хезмәт итүче. *Аэропорт хадиме, ишегенә авыр йозак элеп, матай болгатып киткән лайны озын кунычлы резин итекләре белән ера-ера өенә ашыкты.* А.Гыйләҗев. *Монда телгән кешегә массаж ясаучы хадимнәр дә бар иде, кесә такыррак булганга, мин аларга мөрәҗәгать итмәдем.* А.Тимергалин

3) *күч.* Берәр максатка хезмәт итүче, мәнфәгать, ихтыяҗларны яклаучы. *Ул – чын мәгънәсендә милләт хадиме, милләт йөген төпкә җигелеп тартучы.* Х.Миңнегулов. *Элекке җәмәгать хадимнәре үзләренең чын йөзләре белән ачылалар: наданлыклары, мин-минлекләре, эшлексез һәм мәгънәсезлекләре, комсызлыклары, яңа тәртипләргә дошман булулары белән күз алдына бастырылалар.* А.Әхмәдуллин

**ХАДИМӘ** *и. гар.* 1) Хезмәтче, ялчы хатын-кыз; хезмәт итүче; асрау кыз. *Хадимә, күзен дә йоммыйча, бай абый әйтергә кушмаган иде, мин әйтте димәгез, ул бу ун төннең һичберендә өйдә кунмады, дип кычкырып тора...* Г.Ибраһимов. *– Җәнҗал куптара күрмә, ханбикә, хурга гына калырсың, – дип, хадимә хуҗабикәсен тыеп калды, – башта ханның үзе белән сөйләшеп аңлашу хәерлерәк булыр.* М.Әмирханов

2) Хезмәткәр (хатын-кыз тур.). *Музей хадимәсе үз урынында утырып тора, ләкин мин аны борчымаска булдым – нигәдер ялгыз гына карап йөрисем килде.* Ә.Еники. *Китапханә хадимәсе, өенә кайтырга талпынып, бер – аның иелгән киң җилкәсенә, бер дивардагы шакмаклы кара рам читләгән сәгатьнең өнсезтавышсыз шуышкан чукмар телләренә карап-карап куядыр.* А.Гыйләҗев

3) *күч.* Мәнфәгать, ихтыяҗларны яклаучы. *Мин, бүгенге чор татар баласы, күңеле сынганнарга йөрәк кайнарлыгын бирергә әзер янә бер милләт хадимәсе, заман шагыйрәсе Флёра ханым Гыйззәтуллинаның шигъриятенә эндәшергә киңәш итәм.* Ф.Бәшәр. *[Бик күп образлар] Хатын-кыз геройлар, ир-канатларына илһам бирүче гүзәл ханымнар һәм балаларының киләчәген кайгыртучы аналар булудан тыш, милләт хадимәсе дәрәҗәсенә күтәрелгән үрнәк затлар итеп сурәтләнде.* Л.Галитзуллина

**ХАДИМӘЛЕК** *и. кит. к.* **хадимлек** (хатын-кыз тур.). *Һәрбер килен шикелле, ул да хадимәлектән котылу, үз башына үз ирке белән яшәү турында гел хыялланган икән.* Ә.Еники. *Әмма анда татар шигъриятенә, газиз ана теленә, алар аркылы сөекле халкына тугрылык, хадимәлек, мөкиббәнлек һич тә үзгәрмәде, киресенчә, арта, көчәя генә барды.* Х.Миңнегулов

**ХАДИМЛЕК** *и.* 1) Хадим булу, хезмәтчелек, ялчылык. *Өлкән буын вәкилләре шул яктан аерылып торучан: аларда җитәкчелек вазифасы хадимлектән өстен куелмый.* Г.Шакиров

2) Хезмәткәрлек, хезмәткәр вазифалары, хезмәт итү хәле; берәр максатка хезмәт итү, мәнфәгать, ихтыяҗларны яклау гамәлләре. *Иванов үзенең хадимлек вазифаларын үтәү өчен мөсафирханәгә кайтып киткәч, господин Шубин, үз нәүбәтендә, Ивановтан ишеткәннәрен шул көнне үк господин Андреевка ирештерде.* З.Бигиев

**ХАДИМЛЕ́К ИТҮ** *ф.* Хезмәт итү, хезмәтче булып эшләү; хадим вазифасын башкару. *Хәтта, хадимлек итү өчен, каравылчы карт һәм аның кызларыннан махсус кешеләр дә билгеләнгән иде.* М.Галәү

**ХАДИМЛЕ́К КЫЛУ** *ф. к.* **хадимлек итү**. *Аларның берсе Кырымда калып, икенчесе Санкт-Петербургка китеп хезмәт-хадимлек кылырга тиеш булган.* Мәдәни җомга

**ХАДИСӘ** *и. гар.* 1) Вакыйга, булган эш-хәл. *Ул Мәскәүгә июль башларында кайтасы булса да, Петроградта булган соңгы зур хадисәләр сәбәпле, берничә көннәр кичегергә мәҗбүр булган.* Г.Исхакый. *Бүгенгегәчә башымнан кичкән хадисәнең беразы шушы язылганнардан гыйбарәт булды.* Р.Зарипов

2) Күренеш. *Артта калган халык массасы эчендә фән урынына – табигать хадисәләрен (күренешләрен) ялгыш аңлаулар, төрле булмаган әйберләргә ышанулар, халык тәҗрибәләре, медицина-тыйб гыйлеме урынына – кара имнәр, им-томнар, дөньяга туры караш урынына һәртөрле рухларга, пәри-җеннәргә ышанулар --- йөри.* М.Ибраһимов // Феномен. *Мәсәлән, философия буенча «очраклы күренешләр юк» – һәр очраклы хадисә (феномен) «нинди дә булса закончалыкка буйсына» диелә.* Фән һәм тел

**ХАҖ** *и. гар. дини* Ислам динендә шәригатькә күрә бай саналган һәр мөселманның Корбан гаете көннәрендә билгеле кагыйдәләрне үтәп Кәгъбәне зиярәт итүдән гыйбарәт гамәл. *Дөрес, шундый ук дәрәҗәдәге яисә шуңа якын торган табыш-килешле башка кайбер байларның, халыкка бер генә саваплы эш тә эшләмичә, фәкать үз данnарын күтәрү өчен хаҗга барып, хаҗи исемен йөрткәннәре дә, төрле кызык эзләп шәһәрдән шәһәргә йөреп, башлыча үз мәнфәгатьләрен генә куручеләре дә җитәрлек булган.* Л.Хәмидуллин. *Дөньяны күп гиздем, хаҗда булып, ислам динен кабул иттем, биш намазны калдырмыйм.* А.Гадел

**ХАҖӘТ** *и. гар.* **1.** 1) Кирәклек, ихтыяҗ, зарурият. *«Нигә кырганнар, ни хаҗәте булган?» – дип сора, беркем белми.* А.Гыйләҗев. *Берәр нәрсәгә хаҗәте туса, Мәрзиясен генә йөгерткән була.* Л.Хәмидуллин

2) Кирәк нәрсә. *Хәер, көндәлек хаҗәткә әйләнеп барган китаплар да бар икән.* Б.Рәхимова. *Хәер, колхозга кергәч, бәрәкәтсезлеккә үзем дә өйрәндем, бик хаҗәтне генә кайгырта башладым.* М.Хуҗин

3) Йомыш; теләк, үтенеч. *Ни хаҗәтең килеп чыкты әле алай?* А.Гыйләҗев. *Нindидер Әхмәтнең хаҗәте шулай ук зурмыни аның өчен?* М.Кәбиров

4) Табигый бушануны үтәүгә туган ихтыяҗ. *Олы һәм кече хаҗәтләрен үтәп, тәртә арасында килеш кенә ятып, шактый гомер ял итеп алды.* В.Нуруллин. *Хәтта хаҗәтен дә, көчхәл белән шуышып барып, ишек төбендә генә үтәде.* М.Кәбиров

**2.** *с. мәгъ.* Кирәкле, зарури. *Бик хаҗәт эшләрне бүләргә, Нәбине канәгатьләндерергә туры килде.* А.Гыйләҗев. *Аннары иң хаҗәт хәбәрне миңа өнбаш атакай җиткереп тора.* М.Хәбибуллин

**3.** *хәб. функ.* Кирәк булу. *Көмешең дә хаҗәт түгел – анысы да җитәрлек.* А.Алиш. *Ниемә хаҗәт соң безгә бармак очы хәтле ул маймычлар?!* А.Хәсәнов

◊ **Хаҗәте бар иде** Бер дә кирәге юк. *[Гандәлиф:] Хулиган малаегызның бик хаҗәте бар иде.* А.Гыйләҗев. *Чуртыма хаҗәте бар иде рәссамлыгыңның, дип уйлыйм эчемнән генә.* З.Хөснияр. **Хаҗәте (сукыр) бер тиен** *к.* **кирәге бер тиен**. *Андый политхезмәткәрләрнең хаҗәте бер тиен.* Р.Мостафин. *Синең Җәмиләңнең миңа, майга, балга манып бирсәң дә, хаҗәте сукыр бер тиен!* Д.Салихов

**ХАҖӘТХАНӘ** *и. гар.-фар.* Бәдрәф, әбрәкәй. *Мин, әлбәттә, хаҗәтханә янында тукталып тормадым.* Г.Галиев. *Каралты-курадан хаҗәтханә белән кара мунча гына бар.* А.Зәки

**ХАҖИ** *и. гар.* Хаҗда булып, гыйбадәтләрне кылып кайткан кеше. *Габдрахман хаҗига вакытында үзенең дә файдасы аз тимәде.* С.Поварисов. *Ишектәрәзәләренә бик эләргә әзерләнеп йөргән чакта, Нәҗметдин хаҗиның кечкенә кибетенә алыптай гәүдәле таныш түгел ир-ат килеп керде.* В.Имамов

**ХАҖИБ** *и. гар. тар.* Хан сарайларындагы капкачы, камергер, швейцар. *Бу хаҗиб аларны кызганып еглады.* К.Насыйри. *Би, бәкләр турында сөйләгәч, вәзирнең, олуг хаҗибнең --- нинди булырга тиешлеге турында озынозак бәяннамәләр китә.* Р.Әхмәтьянов

**ХАҖИЯ** *и. гар.* Хатын-кыз хаҗи. *«Һаҗәр» сүзенең хаҗга һәм хаҗияләргә катнашы юк, «һҗр» тамыры күрсәтеп торганча, ул «һиҗрәт», «мөһаҗир» сүзләре белән кардәш.* А.Тимергалин. *Согуд Гарәбстаны короле, махсус савытларга тутыртып, һәр хаҗига, хаҗиягә бүләк тә итеп җибәрә аны [зәм-зәм суын].* З.Сәхабиева

**ХА́Җ КЫЛУ** *ф.* Гарәфә көненнән башлап Корбан бәйрәменә кадәр хаҗга барып, аның аерым йолаларын үтәп, гыйбадәт кылу. *Һәр мөэмин-мөселман гомерендә бер булса да хаҗ кылырга тиеш, ди китап.* А.Хәсәнов. *Мин хаҗ кылырга, Ходай Тәгаләдән ярдәм вә ярлыкау сорарга чыгып китәм.* В.Имамов

**ХАҖНАМӘ** *и. гар.-фар.* 1) *әд.* Хаҗ сәфәре турында көндәлек, юлъязма. *Татар әдәбиятында сәяхәтнамә жанрында иҗат ителгән юлъязмаларның бер төрен – хаҗ кылу максаты белән, исламда изге саналган урыннарга сәфәрне тасвирлаган әдәби ядкәрләрне хаҗнамә дип атап йөртәләр.* Фән һәм тел. *Аларның ничек хаҗ кылулары турында хаҗнамә, сәяхәтнамә яки сәфәрнамәләрдән ачык күренә.* Кызыл таң

2) Хаҗ кылган кешеләргә бирелә торган таныклык. *Аның сүзе җәмәгать алдында моңа кадәр дә үтемле иде, моннан соң да, хаҗнамә өстенә хәтбәчелек таныклыгына ирештереп, бәхеткә күмдерәчәк, һичшиксез!* Ф.Яхин

**ХАИН** *и. гар.* Хыянәтче, сатлыкҗан, вәгъдәсен бозган кеше. *Бигрәк тә ике хаин узына, алар – полицай булып ялланган бәндәләр, күрәсең, хуҗаларына ярарга тырышалар, бәдбәхетләр.* Г.Әпсәләмов. *Исән чакта ычкын моннан, хаин!* В.Имамов

**ХАИНЛЕК** *и. кит.* 1) Хыянәтче булу; сатлыкҗанлык. *Менә бу – синең хаинлегең, түбәнлегең өчен җәза, түз, кабахәт җан, дия идем үземә үзем.* А.Расих

2) Хыянәт, вәгъдәсезлек, җинаять. *Һәр сатлыкҗанның кечкенә куркуы зур хаинлек белән тәмамлана.* С.Поварисов. *Мондый вәхшилекне, мондый динсезлекне, мондый хаинлекне әле тарих хәтерләмиме.* Р.Батулла

**ХАИНЛЕ́К КЫЛУ** *ф.* Хыянәт итү; сату. *Ә Ибраһим агабыз, кабат дистәләрчә еллар яши алган булса да, үз мәсләгенә хаинлек кылмаячак һәм үз партиясен сатмаячак иде!* Ф.Баттал

**ХАИННӘ́РЧӘ** *рәв.* Хаиннәргә, сатлыкҗаннарга хас булганча; хыянәтчел төстә. *Хәзер инде бу яшеренү, хаиннәрчә алдашу аны буганнан-буа барды һәм көннән-көн катлауланган газаплы бер чиргә әйләнде.* А.Расих. *Аның, арабызда берни булмагандай, хаиннәрчә елмаеп сәлам бирүе, тикшерүче кабинетында үзен өендәгечә иркен тотуы җенемне чыгарды.* Г.Тавлин

**ХАЙВАН** *и. гар.* 1) Хәрәкәтләнергә, сизәргә сәләтле һәрбер тереклек иясе. *Ат – үтә сизгер хайван, аңа ышанырга кирәк: җирән кашканың бер дә икеләнмичә, тыныч баруы күңелдә ышаныч уятты.* Р.Низамиев. *Болай да сызланып яткан яралы хайван, ачыргаланып, кызыл йөзлeнең арт санынnan умырып тешләп тә өлгергән иде.* Д.Бүләков

2) Кешеләргә капма-каршы итеп куелган җан иясе. *Алар бит безне хайван урынына исәпләп хурлыйлар, хатынкызларыбызны күз алларыбызда мыскыл итәләр.* Т.Гыйззәт. *Кеше дисәң, мөгезе бар, хайван дисәң, бер дә хайванга охшамаган.* З.Мәхмүди

3) *сөйл. туп.* Тупас, әхлаксыз, тәрбиясез, түбән җанлы кеше турында әйтелә. *Ул бөтенләй алкашлыкка чыгып бара инде: миңа ачуланган була, хайван!* К.Тимбикова. *Алма шикелле малайларын да онытты, хайван.* Ә.Сафиуллин

4) *сөйл. кимс.* Яратмыйча, кимсетеп, ачуланып, әрләп кемгә дә булса эндәшү сүзе. *Син, тинтәк, хайван, сары йорт хакында, монда җан тәслим кылган сабыйлар турында Ионыч әйткән сүзләрне ишетмәдеңмени?* А.Гыйләҗев. *Син үзеңне бел, карт хайван, әнине кем бетергәнен мин яхшы беләм.* Р.Сәгъди

**ХАЙВАНАЗЫК** *и.* Ит, сөт, бал, йомырка, уылдык кебек турыдан-туры хайваннардан алына яки хайваннар бирә торган ашамлыклар; *русчасы:* **животная пища**. *Төньяк Америка опоссумы – мәче кадәр зурлыктагы хайван, үсемлекләр белән дә, хайваназык белән дә туклана.* Биология. *Аннары инде мин тиз үсәм: койрыгым кыскара, ян сызык юкка чыга, тиренең төзелеше үзгәрә, күзләрем зурая һәм күперә, эчемдә дә эчәгем кыскара, хайваназык белән туклануга әзерләнә.* Ә.Әхмәтгалиева

**ХАЙВАНАТ** *җый. и. гар.* 1) Тереклек дөньясы. *Бөтен хайванатны (кошкортларны, кешеләрне) пар-пар яралтты.* Р.Батулла

2) Һәртөрле хайваннар. *Аның чыркылдауларына һәммә хайванат таңгаҗәеп итүдә икән.* Ф.Яхин. *Кешене хайванат дөньясыннан аерып торган өч хикмәт бар: Тел, Моң, Хәтер.* М.Галиев

3) *иск.* Зоология. --- *«хайванат» (зоология), «һәйәт» (астрономия), «гыйльме сәрвәт» (экономика) кебек атаматерминнар да инде узылган этаплар дип каралырга тиеш.* А.Тимергалин

**ХАЙВАНИ** *с. гар.* 1) Хайванга хас; акыл, аң эшчәнлеге, фикерләүгә нигезләнмәгән, бары табигый тойгы белән генә чикләнгән. *Кешедә еланнан курку тойгысы – эволюция мирасы һәм ул, асылда, инстинктлар тирәнлегендә, психик катламнарның хайвани тирәнлегендә үк ята.* А.Тимергалин. *Ул гына да түгел – тормыш шартлары, хосусый милек тәэсирендә тора-бара аның үз характерында да хайвани инстинктлар көчәя.* М.Хәсәнов

2) *күч.* Тупас, түбән, әдәпсез. *– Хайвани гадәт дияргә була, – дип, тыныч кына нәтиҗә чыгарып куйды полковник.* М.Маликова. *Хайвани мөнәсәбәт кенә ерткычлык хисен уята!* Р.Рахман

**ХАЙВАНИЯТ** *и. гар.* 1) *к.* **хайванлык**. *Димәк, рухи дөнья үсеш ягыннан артка кала башлый икән, ул вакытта хайваният вә вәхшилек кануннары өстен чыга һәм кешелекне харап итәчәк.* Ф.Яхин

2) Физиологик теләкләр, табигый тойгылар. *Ирләребез һаман да аларга үзләренең хайваниятләрен үтәргә генә ярый торган мәхлуклар дип карыйлар һәм аларны шул юлда тәрбия итәләр.* С.Җәлал. *Яшьрәк кешеләр аны никадәр идеал белән буяп, үзләренең хыяллары ярдәме белән әллә ниткән әфлатүни гыйшыклар ясап маташсалар да, барыбер инде аның төбе шул хайваниятькә, ирлек-хатынлыкка кайтып кала бит, ахрысы!* Г.Рәхим

3) *күч.* Әдәпсезлек, тупаслык, дорфалык, культурасызлык. *Һәр шәкерт мәдрәсәне әдәпкә өйрәнү һәм әхлак төзәтү урыны дип белеп, үзен хайваниятьтән саклап, инсаният (кешелеклелек) белән зиннәтләргә тырышырга тиеш.* Р.Зарипов

**ХАЙВАНЛЫК** *и.* 1) Хайван булу хәле. *Хайван каны белән безгә хайванның хайванлыгы күчә, тыелган дуңгыз ите аша безгә йөзләгән куркыныч чирләр үтеп керә, аракы, хәмер бездәге иң көчле күзәнәкләрне дә үтерергә, җимерергә сәләтле.* Ф.Бәйрәмова. *Кеше чын кеше булып та бетә алмаган, хайванлыктан да узган инде.* Н.Шәрифуллин

2) *күч.* Әшәкелек, тупаслык, түбәнлек, хайванга (*3 мәгъ.*) хас сыйфат, кылануш. *Ул аның уттай янган, дер-дер калтыранган тәнен тимер кыршау белән кыскан кебек һаман ныграк кысты, ниндидер рәхимсезлек белән, ниндидер хайванлык белән кысты.* Н.Фәттах. *Әйе, кайчак кешене комсызлык, мәгънәсезлек горур «кеше» исеменнән хайванлыкка этәрә шул...* Гасырлар авазы

**ХАЙВАНЧЫЛЫК** *и.* Терлекчелек. *Хайванчылык, агрономлык Белем юкта бик кыен; Мал үрчетмәгән колхозчы, Ударница, бригадирның, Активистка, комсомолның Хакы сукыр бер тиен.* Т.Гыйззәт. *Хайваннарның көтүлекләрдә исән-имин йөрүләре беренче чиратта хайванчылык өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләрнең агулы үләннәр белән танышлыкларына, тәҗрибәләренә, үз эшләрен намус белән башкаруларына нык бәйләнгән.* Агулы үсемлекләр

**ХАЙ-ДА́ЙВИНГ** *и. ингл. спорт* Экстремаль биеклектән суга сикерү. *Хайдайвинг ярышлары – хисләр өермәсе, кеше организмының мөмкинлекләре шулкадәр чиксез булуга гаҗәпләнәм.* Ялкын

**ХАЙП** *и. ингл.* **1.** 1) Реаль керем алу максаты белән, нинди дә булса кеше, әйбер, вакыйга һ.б. тирәсендә шау-шу куптарып, шул хакта күп язып, сөйләп, аларны популярлаштыруга юнәлдерелгән агрессив реклама. *Бүгенге көндә «хайп» төшенчәсе артык активлашып китү сәбәпле, кайбер артистлар тамашачыларын һәрдаим «тонус»та тотарга тырыша, юктан да сәбәп табып, тиз вакыт эчендә зур шау-шу дәрәҗәсенә җиткерәләр.* Сәхнә. *Ютуберлар мәгънәсез видеоларын бер максат белән төшерә: аларга хайп, лайклар, дан кирәк.* Ялкын

2) Зур керемнәр вәгъдә итә торган һәм күбесенчә электрон валюталар белән эш итә торган онлайн проекттан гыйбарәт инвестиция фонды; финанс пирамидасы

3) Шау-шу, ажиотаж; шуның ярдәмендә яуланган танылу, скандаллы популярлык. *Хәзер 1990 нчы еллар стилистикасында хайп (моданың иң югары ноктасы – ред.) зур. Безнең гәҗит. Ул – яшьләр сленгы, хәзерге вакытта модада булган әйберләрне «хайп» дип атыйлар.* Сәхнә. *Татар шигъриятендәге туган авылны, әниләрне сагыну, аның табигатенә дан җырлау мотивлары соңгы вакытта модада түгел (хәзер шигырьдән асфальт исен эзлиләр) я булмаса, хайпта түгел, дип әйтик инде.* Сөембикә

**2.** *с. мәгъ.* Хайпка (*2 мәгъ.*) корылган, хайп белән бәйле. *Бүген финанс пирамидалары, аларны әле тагын хайп проектлар дип тә атыйлар, мошенниклыкның бер төре, интернет челтәрендә киң колач җәяләр.* Безнең Чирмешән

**ХА́ЙПЛЫ** *с. неол.* Агрессив реклама сәбәпле бик нык популярлашкан, аеруча нык танылган; халык телендә булган. *Сыйфатны күтәрү максатыннан, заманча сүз белән бары «хайплы» һәм инде дәрәҗәләргә ирешкән җырчыларны гына чакырырга булганнар.* Э.Габдуллина

**ХАЙ-ХА́Й** *ы.* Бик нык гаҗәпләнүне, соклануны белдерә. *– Хай-хай-хай-хай! – дип сөенешеп утырдылар. – Менә бу ир ичмасам, менә бу егет ичмасам!* Р.Батулла. *– Хай-хай-хай, Әминә, мин синнән моны көтмәгән идем, – дип уфтана иде ул.* М.Яһудин

**ХАК** I *с. гар.* **1.** 1) Чынбарлыкка туры килә торган, чын, дөрес. *Хак сүз әйтеп күпме гомер яшәлгән...* И.Юзеев. *Хак булган шул сүзләре, әнә, безнең авылныкылар, киткәндә, песи кебек юаш кына малайлар иде, арыслан булып кайттылар.* Р.Вәлиев

2) Чын. *Монда бездә хак мөселман агай-эне эшләре генә карала.* К.Тинчурин. *Төрки риваятьләрдә шулай сөйләнелә: кешеләр хак дингә күчәргә теләмәгәч, Алла аларны туфан белән харап итәргә карар кыла.* Н.Фәттах

3) Изге, гадел, туры, намус һәм вөҗданга каршы килмәгән. *Яшьлек хатасының әнисе өчен бик кыйммәткә төшкәнен аңлаган кызы да хак юлга басты, бик күп игелек күрсәтте.* Г.Хәбибуллина

**2.** *и. мәгъ.* Дөреслек, дөрес, гадел эш; кирәкле эш. *Кеше сөйләгән хакны язуы авыр, үзең уйлап чыгарган ялганны язуы җиңел, шулаймы?* А.Хәлим. *Хакны нахактан аерып кабул итәргә, сабак алырга гына кирәк.* М.Маликова

**3.** *хәб. функ.* Дөрес, чынлап та; дөреслеккә туры килә. *Хак, Зәйтүнә кыз, диңгез һавасы сулышларны киңәйтеп җибәрә бит ул, урап кайтыйк, булмаса.* М.Әмирханов. *Әйе, полковник белән булган хәлләр дә хак.* Д.Салихов

**ХАК** II *и. гар.* 1) Хокук, вәкаләт, мөмкинлек. *Ул хакны безнең халык үз каны белән сугышып алды.* Г.Бәширов. *Гөлбакчасын таптар хакым юк.* А.Хәлим

2) Нәрсәдән дә булса (яки ниндидер уртак әйбердән) файдалана алу хокукы; өлеш. *[Кәримҗан:] Бу йортка минем дә хакым бар иде шикелле?*

А.Гыйләҗев. *Мираска, варислыкка хакың бар икән, аңа хуҗа булырга да кирәктер.* Р.Фәйзуллин // Кемнең дә булса өлеше; шәхси милек, мөлкәт. *Төкерәм мин ул бирәннәрнең яшәүләренә, бар да күз яше, бар да кеше хакы.* А.Алиш. *Кеше хакына кермә, улым, харамга кагыла күрмә.* Д.Булатова

**ХАК** III *и. гар.* 1) Бәя, бәһа. *Бу чаклы авыр заманнарда, утын белән күмер хакы шулай үсеп торганда, авыл өйләрен газ белән тәэмин итә алса, һәйкәл куелырга тиеш андый кешегә!* К.Миңлебаев. *Бер-берсенең кием-салымына, балдак-алкасына, иннек-кершәненә бәя бирешкәч, шуларның хакы турында телне шомарткач, иң әрсезе тәкъдим кертә: җәмәгать, ирләребезнең сөяркәләре барын беләбез.* Т.Галиуллин

2) Эш өчен түләү күләме. *Имеш, бер ярым хак арттырылсын!..* Г.Ибраһимов. *Эшләгәне өчен хакны үзе сорап ала белмәгән – кем күпме бирсә, шуңа риза булган.* З.Зәйнуллин

◊ **Хакыннан тормау** Хакы, бәясе кыйммәт булса да алу; бәясеннән тормау. *Гаяз бабай өстәп куйды: – Хакыннан тормабыз, улым, бәхилләтербез, яса гына.* Г.Шәрәфи. – *Таныш табибың булып, [тешне] тиз эшләсәләр – хакыннан тормас идем, – диде ул.* Ә.Зарипов

**ХАК** IV *и. гар.* Кем яки нәрсә алдында бурыч; кемгә яки нәрсәгә дә булса тирән хөрмәт, ихтирам, иң саф хисләр саклаган хәлдә, аны олылау, кадерләү, аңа хезмәт итү, аның өчен барысына да әзер булуны аңлата. *Аллаһы Тәгалә хакыннан соң ата хакы, ата хакыннан соң ана хакы, ана хакыннан соң күрше хакы – иң беренче, иң асыл хаклар.* А.Хәлим. *Тугыз яшьтә генә булса да, Булат белә: ана хакы беренче урында, ул башка бөтен хаклардан да өстенрәк!* Г.Гыйльманов

**ХАК** V *и. гар. дини* Алла, Аллаһы Тәгалә, Ходай. *Дөньядагы бөтен нәрсәнең, шул исәптән кешеләрнең дә асылын Хак тәшкил итә.* А.Тимергалин. *Бәлки, Хак Тәгаләнең кодрәте белән, сугышта шәһит киткән әтисенең шул васыятьләре саклап йөрткәндер аны...* Г.Галиева

**ХАКАН** *и. кыт. тар. к.* **кахан**. *Ханны котлагач, ул утынга ут төртеп җибәрә һәм шуннан соң бөек хакан янына килеп утыра.* Н.Фәттах. *Хәзәр падишасы хакында әйткәндә исә, дәрәҗәсе белән ул хакан (кахан), ул дүрт айга бер мәртәбәдән ары күренми, анда да аны читтән генә күрергә мөмкин.* Р.Фәхретдинов

**ХАКАС** *и.* Хакасия республикасында яшәүче төп халык атамасы һәм шул халыкның бер вәкиле. *Төрекмән, хакас, абхаз һәм башка милләт егетләре дә шул ук сөальләрне бирделәр.* С.Поварисов. *Хәзер инде, үзбәк, башкорт, хакас, уйгур – тугандаш халыклар, дип әйтеп кара, ачуланулары мөмкин.* З.Мурсиев

**ХА́КЕР** *и. ингл.* 1) Компьютер программалары төзү белән шөгыльләнүче кеше; компьютер системаларының бөтен нечкәлекләрен белә торган югары дәрәҗәдәге белгеч. *Безнең хакерлар мондый антивирусларны узарга күптән өйрәнде.* Т.Миңнуллин. *Булат 9 сыйныфта гына укуына карамастан, интернетны һәм заманча технологияләрне профессиональ хакерлардан ким белми, дигән фикер туды миндә.* Л.Локманова

2) Лицензияле программаларны һәм кодларны ватып, компьютер программасына үзгәрешләр кертә торган җинаятьче. *Әлбәттә, җинаять кодексында компьютер караклары – хакерлар өчен махсус матдә каралган, әмма кешелек дөньясының язмышы турында сүз барганда моның белән исәпләшеп торыр чакмыни?* А.Тимергалин. *Хакер – пароль урлап, вирус уйлап чыгарып, сайтларны ватып утыручы программист.* А.Әпсәләмова // Төрле максатлар белән мәгълүмат системаларына, чит кешеләрнең социаль челтәрләрдәге битләренә кереп мәгълүмат алу, булганнарын үзгәртү, алар исеменнән хат-хәбәрләр язу һ.б. хулиганлык кылучы кеше. *Әйтик, күптән түгел генә, «В контакте» кебек социаль челтәрләрдә хакерлар кешеләрнең шәхси битләреннән парольләрен үзләренә генә билгеле булган юллар белән табалар да шул кеше исеменнән хат язалар.* Безнең гәҗит. *Компьютер хакерлары нык сакланган серле кодларны да җимерә.* Кызыл таң

**ХА́КЕРЛЫК** *и.* Хакер хезмәте, хакер вазифасы, эше; хакер булу. *Әлеге дә баягы хакерлыкка өйрәтә торган фирмага илтеп тә бирде.* Ф.Зариф. *Бу хакерлык түгел: мин баш редактор, бу – минем законлы эшем.* И.Фәйзрахманов

**ХА́КИ** *с. фар.* **1.** Яшькелт көрән төстәге. *Әмирҗан брезент плащын һәм хаки фуражкасын салып чөйгә элде.* Ш.Камал. *Әле дә исендә, апасы бүләк иткән иде ул хаки чалбарны ---.* Ш.Мостафин

**2.** *и. мәгъ.* 1) Яшькелт көрән. *Аның өстендә гәүдәсенә сыланып торган, хаки төсендәге бик килешле өр-яңа китель.* И.Салахов. *Әкәмәт малай ул – өстендә бугазына кадәр төймәләнгән яшькелт хаки төсендәге китель, пөхтә чалбар, тик лампаслары гына юк.* Р.Мирхәйдәров

2) Шул төстәге тукыма. – *Биючеләргә костюмнар тегәр өчен, бернichә метр хаки алырга кирәк, җепләрем дә бетеп килә, – диде апасы, җыенаҗыена.* Сөембикә

3) Шундый материалдан тегелгән, гадәттә хәрбиләр, геологлар, балыкчылар, аучылар һ.б. кия торган махсус кием. *Алар чит илнекеләр булса кирәк. Өсләренә хаки кигәннәр.* М.Юныс

**ХАКИМ** *и. гар.* **1.** 1) Идарәче, башлык, хуҗа, түрә, мөдир; хакимлек итүче. *Хаким буласы килү – кеше холкының иң гаҗәп бер дәртедер.* Р.Хәкимов. *Әйе, хаким белән халык арасындагы каршылык адәм баласының табигатенә үк салынган инде.* З.Хөснияр

2) Хөкем итүче, хөкем чыгаручы; судья; казый. *Ришвәт – үз файдасына хөкем итсен яки сүз сөйләсен һәм тавыш бирсен өчен, казый һәм хакимнәргә, кулларында эш булган кешеләргә бирелә торган мал һәм бүләк.* Р.Фәхретдин. *Болар – хакимнәр һәм казыйлар, ягъни мөселман кануннары нигезендә хөкем чыгаручы судьялар; полиция, таможня, чик буе хезмәткәрләре, илчеләр, төрле вәкилләр.* Р.Фәхретдинов

3) *спорт* Арбитр, судья. *Хакимнәр проблемасы хәл ителде, арбитрлар мәктәбе эшли.* Йолдыз. – *Ләкин тренерлар китү сәбәпле, командалар таркалды, – дип билгеләп үтте ярышлар хакиме Геннадий Горбатов.* Авыл таңнары

4) *күпл.* Хакимият ияләре, югары сыйныф кешеләре. *Ачыграк әйтсәк: егерменче гасыр башында илне һәм халыкны изә-изә, талый-талый шушы фаҗигале хәлләр килеп чыгуга сәбәпче булганнар икән – димәк, Рәсәй патшасы һәм, гомумән, байлар, хакимнәр катламы фәрештә кебек изге булмаган инде алар!* М.Вәлиев. *Кыскасы, дин халыкка түгел, хакимнәргә хезмәт итә, чөнки халыкны «үз ирке» белән аларның коллары итә.* З.Мурсиев

5) *күч.* Беренче урында, алгы планда булган нәрсә яки өстен көч. *Вакыт – хаким, һәркемне дә үзе сыный, Алашадан, көчәнсә дә, шигырь тумый.*

Н.Әхмәдиев. *Шигырь хаким булса да, Шагыйрь хаким булалмый.* Р.Миңнуллин

**2.** *с. мәгъ.* Ил, дәүләт белән идарә иткән, югары сыйныфтан булган. *Хаким затларга барысы да берьюлы кирәк.* Ф.Латыйфи. *Югарыдагыларга, хаким сыйныфка ярдәм итәргә теләүчеләр һәрвакыт һәм һәр буыннан табыла тора!* М.Хәсәнов

**ХАКИМИЯТ** *и. гар.* 1) Хакимлек; власть. *Хакимияткә калу*

2) Хөкүмәт, дәүләт идарәсе. *Бу очракта җирле хакимият башлыкларыннан күп нәрсә тора.* Р.Фәйзуллин. *Сез – җитез, өлгер, әрсез ир-егет, әнә хакимият баскычыннан ничек тиз йөгереп менеп киткәнсез, өстәгеләргә ялагайлану таланты сирәк кешегә бирелә.* Н.Гыйматдинова

**ХАКИМИЯТЧЕ** *и.* Хакимият вәкиле, хакимият, дәүләт идарәсе әһеле. *Совет хакимиятчеләре Исхакыйны «буржуаз миллиятче һәм капиталистлар ялчысы» дип телгә ала.* Г.Акыш. *Тоташ яһүдләрдән, террористлар өереннән торган хакимиятчеләрнең кыяфәтләре аларның кемлеген ачып сала.* Р.Зарипов

**ХАКИМИЯТЧЕЛЕК** *и. ялг.* Ил, дәүләт белән идарә итүчеләр; хөкүмәт башындагылар. *«Вазифасыз язучы – язучы түгел» дигән әйтем хәзер дә үз көчендә, ул бигрәк тә дәүләт хакимиятчелеге тирәсендә хөкем сөрә.* Н.Нәҗми. *Башкортстан хакимиятчелегенең татар милләтеннән башкорт ясамакчы булып тарткалашуын да шуның белән аңлатырга кирәк.* Н.Сафина

**ХАКИМЛЕК** *и.* 1) Хаким булу; хуҗа, түрә, башлык дәрәҗәсе. *Гера аны байлык һәм хакимлек белән ымсындыра.* Г.Хөсәенов. *Алар уйлавынча, хакимлек көче аларның кулларына үзе килеп керә дә, халыкны тагын тигез сафларга бастырып, бәхетле киләчәккә алып китәчәкләр, имеш.* Я.Шәфыйков

2) Хакимият, власть; дәүләт белән идарә итү хокукы. Баштагы мәлдә хакимлек руслар ярдәмендә Мөхәммәд Әминдә булса, соңрак нугайларның хәрби отрядлары ярдәмендә Алиханга күчә. Т.Кәримов. Ачыктан-ачык хакимлек урнаштыргач, без бөтен кануннарны да үзгәртеп бетерәчәкбез: безнең законнар кыска, аңлаешлы, берничек тә боргаланмый торган булачак. М.Кәбиров

3) Өстенлек; өстенлек итү, идарә итү, баш булу. *Әби патша юллары да, татар өстеннән Мәскәү хакимлеге дә, буйсынмаганнар өчен Себер төрмәләре дә исән бит әле.* Т.Нәҗмиев

4) *күч.* Нәрсәнең дә булса башкаларга караганда өстенлеге; күбрәк, артыграк булуы. *Күңелне туктаусыз актарып торган газаплы уйлар хакимлегендә алдагы кичне көтәсе калды.* Н.Әхмәдиев. *Табигатьтә кыш үзенең хакимлеген урнаштыра.* Т.Нәҗмиев

**ХАКИМЛЕ́К ИТҮ** *ф.* 1) Хуҗа булу, өстенлек итү. *Нишләптер, гел бүтәннәр өстеннән хакимлек итү белән саташалар.* Ш.Галиев. *Заман кемнең кулында, Шулар хакимлек итә.* С.Әхмәтҗанова

2) Хакимият башында тору, идарә итү. *– Кенәз, минем һич тә хакимлек итүемне җәзадан башлыйсым килми, – диде Василий, озак кына уйланып торганнан соң.* М.Әмирханов. *Илләр белән императорлар, патшалар, президентлар, корольләр, ханнар хакимлек итә.* Р.Миңнуллин

3) *күч.* Колач җәю; хөкем сөрү. *Урман өстендә күк яктылыгы чагылып калгаласа да, аста инде эңгер-меңгер хакимлек итә.* Г.Гыйльманов. *Җиһанда әбиләр чуагы хакимлек итә иде: бер-берсе белән куышлы уйнаган тоҗымнар, әрфия канатларын тибрәтеп, әле монда, әле тегендә килеп сарылалар.* А.Әхмәтгалиева

**ХАКИМЛЕ́К КЫЛУ** *ф. к.* **хакимлек итү**. *Шигырь түрендәге алтын тәхеттә Шагыйрь Мөдәррис хакимлек кыла.* Р.Батулла. *Син нигә гел үзең хакимлек кыласың?* Г.Каюмов

**ХАКЛА́У** *ф.* 1) Даулау, яулау, яклау; дәгъва итү. *Үз хакыңны хаклап сүз әйтерлек чама юкмыни синдә?!* А.Гыйләҗев. --- *Маңгаена сукты Абсолютның. Сукты Галилейлар үчен алып, Коперниклар сүзен хаклап сукты...* Л.Лерон

2) Олылау; хакын тану; хаклы дип санау, исәпләшү; хөрмәт белән карау, санлашу. *Безнең хакны хаклар, аштан олы булмас идең, энекәш?* В.Имамов. *Ә бит дөрес әйтәсең: башта уку, дидек, аннары, фатир булсын, дидек, фатир алганга да ике ел… Бала хакын хакламагач, нинди яшәү ул?!* Г.Гыйльманов

**Хаклап йөрү** Гел хаклау; озак вакыт хаклау. *Бәс, алай икән, нигә ул әтиләре авылында гаделлек хаклап йөргән булды?* А.Гыйләҗев. *Һаман шул гомер бетмәс күрше хакын хаклап йөрү инде.* Н.Гариф

**Хаклап килү** Күптәннән бирле хаклау. *Үз хакын гына хаклап килә шул андыйлар.* Р.Вәлиев

**Хаклап тору** Әле, хәзер яки һәрвакыт, гел хаклау. *Күз яшедәй чиста шигърият Меңәр гасыр, диләр, кимендә: Вөҗдан өлгеләрен хаклап тора, Күк гөмбәзен тотып иңендә.* Ф.Гыйззәтуллина. *Вакытыңны саклап торма, Хаклап тор!* Н.Сафина

**Хаклый башлау** Хакларга керешү. *Бу миндә бераз шикле уйлар тудырды: әгәр шушы халыклар, үзара берләшеп, зур көчкә әйләнсә һәм үз хакларын хаклый башласа, бу, киресенчә, Россиянең таркалуына китермәсме?* Р.Гыйлемханов

**ХАКЛЫ** I *с. иск.* Кыйммәтле, бәһале. *Хаклы нәрсә – затлы нәрсә.* Мәкаль

**ХАКЛЫ** II *с.* **1.** 1) Урынлы, дөрес. *Синең хаклы сүзең, урманның берничә агачтан гына тормавы искә төшә.* Х.Туфан. *Элеккеге фирка җитәкчеләренең берсе – хәзерге генерал – ифрат хаклы, акыллы сүзләр чәчә иде.* Т.Галиуллин

2) Тиешле; үзенә тиешле булган, өлешенә тигән. *Нажар минутлар эчендә шуны ачыкларга тырышты: күзгә күренеп торган ерткыч хаклы җәзасын татыгач, кешеләр тәмам тынычлана алырмы?* Ә.Баян. *Чөнки горурланыр өчен ныклы нигез, хаклы сәбәпләр бар.* Р.Фәйзуллин

3) Дөрес уйлый, фикер йөртә, эшгамәл кыла торган. *Югыйсә без өлкәннәр гел хаклы гына булмыйбыз.* Ф.Яруллин

4) Хакы булган, лаеклы булган. *Ә бу байлыкларның хаклы варисы Хәсәнне коллыктан ни дип йолкып алырга?* А.Хәсәнов. *Хатын-кыз, ир хатыны, балалар анасы булу белән бергә, иҗат итәргә, җәмгыятьтә лаеклы урын алырга хаклы шәхес тә.* М.Маликова

**2.** *рәв. мәгъ.* Дөрес, урынлы рәвештә. *Хаклы шомлангансыз, Кәримҗан ага, аптырашта калдым – Тәзкирәм өйдә юк.* А.Гыйләҗев. *Ни генә булса да, хаклы шауладылар, хаклы бәхәсләштеләр, хаклы бәяләделәр.* Р.Фәйзуллин

**3.** *хәб. функ.* 1) Хокукы бар, хакы бар; хокуклы, лаеклы. *Мондый йолдызлы кешеләр теләсә нинди машинага бушлай утырып йөрергә хаклы.* Ф.Яруллин. *Син яшәргә хаклы, син – бу җирнең герое!* Д.Салихов

2) Дөрес уйлау, дөрес юлда, дөрес фикердә булу турында. *Сүз дә юк, ул якларын да исәпкә алсаң, хатыны хаклы иде.* М.Хәсәнов. *Аның бер гаебе дә юк, ул тулысынча хаклы, һәм аны монда тикшереп тору да кирәкми!* З.Зәйнуллин

**ХАКЛЫК** *и.* 1) Дөреслек, чынлык, хакыйкать, чынбарлыкка туры килү. *Чөнки, үзең ярлы булсаң да, күршең бай булсын, дигән ярым шаяртулы сүзләрдә хаклык барлыгына торган саен ныграк ышана килә иде.* Ф.Яруллин. *– Аларның сүзләрендә дә күпмедер хаклык бар иде бит, бабай, – дип, аның йөзенә күтәрелеп карады Тимерхан.* Р.Вәлиев

2) Гаделлек. *Байрак тотып үлемсезлеккә барган ул кешене, терелтеп, тыныч көнкүрешкә кайтарасы иде, тормышта хаклык өчен көрәшүче, үзен аямаучы комиссар булсын иде.* Ш.Галиев. *Хаклык эзләп, йөзләгән суд утырышы булгандыр.* Г.Газиз

**ХАКЛЫЛЫК** *и.* Берәүнең әйткәне, кылганы дөрес булу, хаклык аның ягында булу. *Юк, без балаларны җәзалыйбыз, дигән логикага таяна алмыйбыз, дип куйды парторг, ниндидер җиңүле хаклылык үзе ягында булган төстә.* Х.Камалов

**ХАКСЫЗ** I *с. сөйл.* **1.** Буш, түләүсез, түләнми торган. *Хаксыз эшкә кем дә урнаша ул, акчалы эшне каян табарга?* Р.Вәлиев

**2.** *рәв. мәгъ.* Бушлай, хак алмыйча. *Хаксыз эшләргә яратмый шул хәзерге яшьләр, яхшы эш тапмаса, ике-өч дипломын кочаклап, өйдә утырырга да мөмкин.* Сөембикә

**ХАКСЫЗ** II *с.* **1.** 1) Хокуксыз, юридик көчсез; вәкаләтләре булмаган. *Кайтып доклад ясагач, групком Миңлебаевның юлын хаксыз тапты.* Г.Ибраһимов. *Соңыннан ул карарның хаксыз булуын рәсми рәвештә таныдылар.* Р.Вәлиев

2) Канунсыз, законсыз; рөхсәт ителмәгән, ярамаган. *Хаксыз эшкә тотынуыңны сизенәсеңме?* А.Гыйләҗев. *Шундый әһәмиятле мәсьәләдә аларга үз белдегенчә эш кылырга рөхсәт ителгән икән, башка мәсьәләләрдә дә алар хаксыз юлдан китеп бармаслар, дигән гарантия юк.* Р.Хәкимов

**2.** *рәв. мәгъ.* Канун бозып, законга каршы килеп, хокукы булмый торып. *Сине дә бит хаксыз рәнҗеттеләр, Дөреслекне эзләп чабарбыз, – Табарбыз...* И.Юзеев. *Ике арадагы дуслык солыхын хаксыз бозган өчен, Сөләйман солтан галиҗәнаплары сине нык гаепли.* В.Имамов

**ХАКСЫЗЛЫК** *и.* 1) Хокуксызлык. *Менә шул – үлем белән, җәбер-золым һәм хаксызлык белән көрәш рухы бездә бишектәге заманнарда ук баш калкыткан.* Н.Фәттах. *Гарифҗан Сәхипов корган тозак шапылдап ябылды да Бакыйның язмышын хаксызлык йозагына бикләп тә куйды.* Ә.Гаффар

2) Законсызлык, канунсызлык. *Хаксызлык корбаннары бихисап.* Ш.Галиев. *Шуңа күрә, Русиядә генә хаксызлык, без ахмаклар илендә яшибез, дип баш катырмагыз.* Л.Заһидуллина

3) Гаделсезлек. *Дөньяда хаксызлык барын тойсаң да, көрәшкә чыга алмыйсың...* А.Гыйләҗев. *Берәр җирдә хаксызлык күрсәм, дәшми тора алмыйм.* И.Шиһапов

**ХАКТА** *бәйл.* Турыда, турында. *Аның гына түгел, Ленизаның да ышанасы килми иде булса кирәк, чөнки көннәр уза торды, алар арасында бу хакта ачыктан-ачык сөйләшү булмады.* М.Маликова. *Ишетү түгел, бу хакта уйласа да, Рәхимҗанның бала йоннары кабара.* А.Әхмәтгалиева

**ХА́К ТӘГАЛӘ** *и. дини* Аллаһ, Аллаһы Тәгалә, Ходай. *Хак Тәгалә, бу баланы юатып күңелен күргәне өчен, әлеге явызның бар гөнаһларын гафу итеп, мәрхәмәтен салган, ди.* Ф.Яруллин. *Хак Тәгалә ризалыгына ирешкәннәргә мәңгелек яшәү хокукы иңдерелгәнен исеңдә тот!* Р.Сафин

**ХАКЫ́ЙКАТӘН** *рәв. гар.* **1.** Чынлап, чынлап торып, дөреслектә. *Ул хакыйкатән дә саран вә тәрбиясез кеше иде.* Г.Ибраһимов. *Русия мөселманнарының хәлләре хакыйкатән бик күп үзгәрергә мохтаҗдыр.* Г.Исхакый

**2.** *кер. сүз.* Дөрестән дә, чыннан да, ихластыр. *Хакыйкатән, Даниил 1522–1539 еллар арасында митрополит вазифаларын башкара, Макарий исә 1542 елдан шул урынга утыртыла.* Р.Батулла. *Хакыйкатән, Сибгат Хәким дөрес әйткән: премия ул язучыны боза гына.* Р.Мөхиярова

**ХАКЫ́ЙКАТЬ** *и. гар.* 1) Дөреслек, хаклык; дөреслеккә туры килгән факт; нәрсәнең дә булса дөреслеге, чынлыгы. *Аннары, аның алдында чын хакыйкатьне әйтергә ярыймы соң дигәндәй, Зөһрә ягына ым кагып куйды.* М.Хәсәнов. *Сафа Гәрәй ханның уйлары хакыйкатькә якын иде.* Р.Батулла

2) Белем һәм тәҗрибә ярдәмендә сыналган, тикшерелгән фикер, караш. *Бәлки, аның гомере буена әкренләп төшенгән һәм үзе генә белгән зур бер хакыйкате бардыр, ихтимал, шуңардан аңа ялгызлыгын җиңеләйткән чын юаныч килә дә торгандыр.* Ә.Еники. *Мәгълүм хакыйкать бар: бәхетне аны эзләп түгел, эшләп табалар.* М.Хәсәнов

3) Чынбарлык, дөрестән дә булган нәрсә; тормышта булган әйбер. *Мәктәптә чакта вәгъдә ителгән томанлы мөмкинлекләр белән тормыш хакыйкате арасындагы аерманың ни дәрәҗәдә зур һәм тирән булуын көннән-көн төшенә барган саен, каушау һәм аптырау тойгысы да көчәя барды.* Н.Фәттах. *Бу ниятен ачы хакыйкать күсәк белән Сабантуйда ватылган чүлмәк кебек чәлпәрәмә китерде.* Т.Галиуллин

4) Әхлакый идеал буларак дөреслек, гаделлек. *Берсе, татар булганга күрә, үзе теләгән чинга күтәрелә алмаган, бердәнбер баласын, хакыйкатькә ышанычын, Ватанын, моңа кадәр табынган идеалларын югалткан.* Р.Рахман. *Хакыйкатькә ышанганнарның күзендә – яктылык.* Мәдәни җомга

5) *филос.* Объектив чынбарлыкта булган нәрсәләрнең кеше аңында дөрес, төгәл чагылышы. *«Кешегә чикләнмәгән хакыйкатькә, ягъни абсолют хакыйкатькә ирешү сәләте бирелмәгән, шунлыктан ул нисби хакыйкать белән канәгатьләнергә мәҗбүр», – диләр галимнәр.* А.Тимергалин. *Объектив хакыйкать күп кенә субъектив хакыйкатьләрдән җыела.* Р.Мостафин

**ХАКЫЙКЫЙ** *с. гар.* 1) Дөрес, чын, чынбарлыкка туры килә торган. *Ә чикләүнең иң кулай юлы күптән билгеле: халык арасында чын, хакыйкый фәнне фәрештәле каләм ярдәмендә армый-талмый тарату һәм популярлаштыру.* А.Тимергалин. *Юк, бу – матур сүз уйнату гына түгел, бәлки Зөлфәт шигъриятенең асыл сыйфатын ачыклаучы символик сурәт, хакыйкый чынбарлык.* Н.Гамбәр

2) Тулы хокуклы. *Аның балалар хирургы, уролог, медицина фәннәре докторы, профессор, ТАССРның һәм Россия Федерациясенең атказанган табибы, Россия Медицина-техника фәннәре академиясенең хакыйкый әгъзасы, --- ТРның Дәүләт бүләге лауреаты икәнен күпләр белә.* Т.Нәҗмиев. *Флёра Сафиуллина – филология фәннәре докторы, профессор, Татарстанның атказанган укытучысы, --- Халыкара төрки академиянең хакыйкый әгъзасы.* М.Садыйков

**ХАКЫНА** *бәйл.* 1) Ихтирам йөзеннән; кем яки нәрсә хөрмәтенә. *Хәдичә Мөхәммәднең пәйгамбәрлегенә беренчеләрдән булып ышана һәм аның изге иманы хакына көчен дә, байлыгын*

*да кызганмый.* А.Тимергалин. *Фәтхи абзый да кунак хакына эшен бүлеп кайтып җиткән.* З.Мәхмүди

2) Өчен. *Эш-тормышының тамак хакына хезмәт итүгә тигезләү иҗат кешесе өчен үлемгә тиң...* А.Гыйләҗев. *Мәрьям исә, замандашларының һәм килер буыннарның бәхете хакына, моңарчы күрелмәгән гүзәл кала торгызу турында хыяллана.* М.Маликова

**ХАКЫНДА** *бәйл. к.* **хакта**. *Сабан туенда катнаша алмаган атларның тамактан язулары хакында сагынып, сагышланып искә төшерә.* Ф.Яруллин. *Гөлфинурның авырып ятуы хакында күбесе белми иде.* А.Вергазов

**ХАЛАТ** *и. гар. 1)* Азиядәге кайбер халыкларның төймәләмичә генә кия торган җилән сыман өске киеме; чапан. *Аны башына дүрт кырлы үзбәк түбәтәе, өстенә буй-буй халат кигән ак сакаллы бер бабай китерә.* Р.Габделхакова

2) Кием өстеннән киелә, гадәттә алдан эләктерелә һәм форма булып санала торган махсус эш киеме. *Пальто өстеннән ак халат кигән бер апа студентка охшаган бер егет белән Искәндәрнең ярасын юдылар да башын бинт белән бәйләделәр.* М.Мәһдиев. *Шулвакыт кухня ягыннан ак халат кигән юантык гәүдәле Юныс Әхмәтҗанов чыгып, безне авыр хатирәләр ташкыныннан йолып калды: – Исәнмесез, мөхтәрәм кардәшләр!* А.Тимергалин

3) Төрле материалдан тегелә торган, күлмәккә охшаш, әмма каптырмалары, эләктергечләре булган көндәлек өй киеме. *Өстенә гади халат кигән, кара чәчләрен баш өстенә җыеп куйган бу аксыл йөзле ябык хатын илленче елларда төшерелгән кинолардагы тыйнак ханымнарны хәтерләтә иде.* Р.Габделхакова. *Хәмзә яңа гына эштән кайтып, юынып кына чыккан икән әле, өстендә йомшак халат, йөзе кызарып, эсселек бөркеп тора.* Ж.Дәрзаман

**ХАЛӘТ** *и. гар.* 1) Хис-кичерешләргә яисә төрле тәэсирләргә бәйле хәл, кәеф, тойгы, рәвеш. *Бу халәт аның йөзенә үк чыккан иде кебек.* М.Хәсәнов. *Бу әйтеп-аңлатып биралмаслык ләззәт, бернәрсә белән дә чагыштырып булмаслык якты бер халәт иде.* М.Кәбиров

2) Нинди дә булса күренеш; торыш. *Шундый татлы, Ләззәтле бер халәт тирәмдә: Яр читендә сары каз бәпкәсе Борынын төрткән яшел чирәмгә...* Р.Вәлиева. *Шуннан соң сурәтләнгән матурлык табигатьнең тынлыгы тудырган гаҗәеп бер халәт итеп күрсәтелә.* Д.Заһидуллина

3) *ялг.* Торыш, поза, хәл. *Мин беләм, мин күз алдына китерәм: Садыйка түтинең һәм әнинең буш булган сул һәм уң куллары исә түбәндә, кайчыларын кысып торткан халәттә, караңгылыкны сөзеп, алга баралар...* А.Хәлим. *Ашыга-кабалана чишенү бүлмәсенә узды да, эскәмиягә утырып, чәчәкләрне янәшәсенә куйды һәм аяк киемен салырга дип иелгән халәтендә катып калды: нәкъ шул минутта ишек төбендә кызларның чырык-чырык сөйләшкәне ишетелде.* А.Әхмәтгалиева

**ХАЛИ** *хәб. гар.* 1) Азат (нәрсәдән дә булса). *Адәми зат ялгышлардан хали түгел, Рәхмәтеңнән ташлый күрмә, читкә какма.* Т.Миңнуллин. *Безнеңчә, Аллаһ олыгаю, картаю, искерү кебек сыйфатлардан хали, аның өчен вакыт дигән нәрсә юк, кичәге, бүгенге һәм иртәгесе көннәр аңарда бер мизгел булып, бергә оешып яшиләр.* А.Тимергалин

2) Мәхрүм, буш. --- *[адәм] мәгърифәттән хали вә буш; золым вә хатасы күп булыр, уңга-суңга күп карар.* К.Насыйри. *Кунаклар килү файдадан хали булмады.* Г.Исхакый

**ХАЛИКЪ** *и. гар.* «Яратучы», «бар итүче» мәгънәсендә Аллаһы Тәгаләнең эпитеты. *Моннан аңлашыла ки, мәкальнең элеккерәк текстында сүз халык (народ) түгел, ә халикъ (яратучы, бар кылучы, ягъни Аллаһы) турында бара икән.* Х.Мәхмүтов. *«Бар итү» төшенчәсе Корьәндә күпчелек гарәп телендәге «халикъ» тамыры аша гәүдәләнделәр.* Д.Абдуллина

**ХАЛИС** *с. гар. кит.* 1) Чын, саф; һичнәрсә катнашмаган; табигый, катнашмасыз. *Тукайны табигать безгә эшләнмәгән, халис көенчә бирде.* Р.Фәтхрахманов. *Һәркем укыса аңларга мөмкин халис татар теле берлән язылган.* Фәнни Татарстан

2) Чын, эчкерсез, ихлас. *Халис булмаган гамәл иң азы мәкруһ булырга тиешле.* Р.Фәхретдин. --- *актык тамчы каннарыгыз калганчы дошман илә сугышачагызга халис күңелемнән ышанамын.* Ш.Мөхәммәдев

**ХАЛТУ́РА** *и. лат. сөйл.* 1) Өстәмә керем өчен, төп эштән тыш өстәмә эш, шабашка. *Ләкин фабриканың директоры, аңа кадәр яшәп килгән тәртипләрне үзгәртмичә, җиңел юл белән генә, сыбызгылар ясап, халтурадан акча туплап, шулар хисабына яңа машиналар – станоклар кую уңышына ирешергә теләп, консерваторлык күрсәтә.* Т.Гыйззәт. *Мин халтура белән шөгыльләнмим, кәсепче дә түгел.* Р.Кәрами

2) Җиңел юл белән читтән эшләп алынган керем, эш хакы. *Халтура белән шөгыльләнү – чын сәнгатькә хыянәт.* М.Әмир. *Уңышсыз әсәрләрем бардыр, тик берсе дә халтура өчен язылмады.* Т.Миңнуллин

3) Өстән-өстән генә эшләнгән начар сыйфатлы эш. *Аларның күбесен кире борырга, чүп савытына ыргытырга, шигырь түгеллекләрен дәлилләргә – халтура белән көрәшергә шулай ук күп көч сарыф итәргә кирәк бит.* Р.Миңнуллин. *– Кеше, вакытын әрәм итеп, халтура карарга килеп утырмый, шуны истән чыгармагыз, – дип, әллә ничә кисәтте үзләрен.* А.Әхмәтгалиева

**ХАЛТУ́РАЛАУ** *ф. сөйл.* 1) Халтура белән шөгыльләнү; шабашка эшләү. *Акча кирәк булган чакларда халтураларга да туры килә*

2) Өстән-өстән генә эшләү; тиешле дәрәҗәгә җиткермичә эшләү. *Драматургиядә ике төр кешеләр җиңә – талантлар һәм халтурачылар.* А.Гыйләҗев. *Мөтәшагыйрь шигырь сырлаганда Халтуралап, Онытып оятын да, Ник торасың, Иҗат, бусагада, Урыныңмы ишек катында?* Р.Әхмәтҗанов

**ХАЛТУ́РАЧЫ** *и. сөйл.* 1) Халтура белән шөгыльләнүче. *Сәхнәгә халтурачылар кирәкми дибез!* Р.Батулла

2) Эшне җиренә җиткермичә, сыйфатсыз башкаручы. *Драматургиядә ике төр кешеләр җиңә – талантлар һәм халтурачылар.* А.Гыйләҗев. *Сүз уңаеннан әйтим әле, бары тик талантлы кеше генә халтурачы була ала.* Р.Батулла

**ХАЛТУ́РАЧЫЛЫК** *и. сөйл.* Халтуралау күренеше. *Аның безнең әдәбият өлкәсендәге барышында без богемачылык, елаклык, пессимистлык, ачыктаначык халтурачылык («Калфаклылар» кебек) элементларының гаять көчле булуын күреп килә идек.* Ф.Галимуллин. *Татар җыр сәнгате 80 нче елларга кадәр гел үсештә барып, 90 нчы еллардан халтурачылык, зәвыксызлык чәчәк ата башлау мине таң калдырды.* Мәдәни җомга

**ХАЛЫК** *и. гар.* 1) Кешелек; гомумән кешеләр. *Җир шарындагы җиде*

*миллиард халыкның ике миллиардын мөселманнар тәшкил итә.* А.Хәлим

2) Нинди дә булса бер илдә, дәүләттә яшәүче кешеләр; әһали. *Безнең данлыклы кораллы көчләребез, илебез халкы кешелек дөньясын һәлакәттән алып калды.* Т.Гыйззәт. *Нишләп илебез халкы надан булсын?* Л.Лерон

3) Аерым бер территориаль чикләрдә (шәһәр, район, авыл һ.б.) яшәүче кешеләр. *Икенчедән, шәһәр халкы сихәтле су күрсен өчен акча бирергә тиешле кешеләр үзләре күптән инде чишмә суы гына эчә, ташпулатларына бакчаларында хәтта икешәр кое бораулаталар.* К.Кәримов. *Шуннан соң бөтен авыл халкы, теше сызласа, минем янга килә торган булып китте.* Аманулла

4) Милләт; бер милләт кешеләре. *Сезнең кебек кеше башка халыкларда булса, әллә кайчан академик итәрләр иде.* Г.Әпсәләмов. *Татар халкының җир йөзендә башка халыклар белән бер хокукта яшәве өчен көрәш гасырлар буе дәвам итә.* Т.Миңнуллин

5) Җәмгыять; җәмәгать. *Турысын әйтик: без барыбыз да халык фетнәсеннән куркабыз, чөнки фетнә берәүне дә аямаячак, һәм беренче чиратта – ничәнче тапкыр! – милләтнең иң зыялы кешеләре, иң нәфис чәчәкләре харап булачак...* А.Тимергалин

6) Илнең төп хезмәт ияләре массасы. *Ә гади халык элек тә күкрәге белән илне саклаган, Алла боерса, хәзер дә теше-тырнагы белән саклар.* З.Мәхмүди. *Үсеп зур булырга, зур кеше булып, халык бәхете өчен үзенең бөтен көчен бирергә – ул менә шундый теләкләр белән янды.* А.Алиш

7) Бер урынга җыелган кешеләр; кешеләр төркеме. *Монда да халык аннан җавап көтте кебек, әмма беркем дә берни сорамады.* М.Мәһдиев. *Ишанның вәгазеннән соң, ишегалдындагы халык шаулаша башлады.* З.Зәйнуллин

8) Билгеле бер даирә, төркем, сословие, һөнәр иясе кешеләре. *Әгәр дә мәгәр Вагонстрой халкыннан арыслан йөрәкле берәрсе табылып, ике чемоданга салынган нинди киемнең кемнән алынган икәнен күрсәтеп, исемлек төзесә һәм әйбер-кара ияләреннән куллар куйдырса, анда базардан сатып алынган бер генә әйбер дә юклыгы тәгаенләнгән булыр иде.* К.Миңлебаев. *Укытучы халкыннан мин әлегә беркемне белмим.* Н.Фәттах

9) Хөкүмәт тарафыннан иң югары хөрмәт билгесе буларак бирелә торган кайбер мактаулы исемнәрнең бер компоненты. *Татарстанның халык артисты Айрат Арсланов шагыйрьнең шигырьләрен йөрәккә үткәреп укыды.* Н.Нәҗми. *Татар дөньясының каһарман халык шагыйре, Тукай премиясе лауреаты, 51 китап авторы Фәнис Яруллин, баш өстенә кулын куеп саубуллашып, Камал театры каршыннан мәңгелек йортка күчте.* Г.Галимуллина

10) *җый. и. сөйл.* Мәхлуклар буларак хайван, кош-корт һ.б.ш. турында. *Сания Хәлимне таңга кадәр саклап утырды, аның тирләп чыккан битен сөрткәләде, таңда кояш яктысы белән котыра башлаган чебен халкын якын җибәрмичә куып торды.* Г.Гыйльманов. *Дөрес, бу авылда кәҗә халкыннан инде башка берәү дә калмаганга, ул үз токымының соңгысы иде.* Р.Рахман

11) Терминологик тезмәләрдә «халыкчан», «демократик» мәгънәсен белдерә торган кисәк. *Халык демократиясе илләренә ул Франциянe һәм Бенилюксны кертеп харап булган.* М.Мәһдиев. *Анда, гадәттәгечә, Үзәк дәүләт курчак театры адресына җылы сүзләр яңгырый, тамашачылар һәм белгечләр халык демократиясе илләреннән килгән яшь театрларның спектакльләре белән кызыксыналар.* Р.Игъламов

12) Кайбер терминологик тезмәләрдә «иҗтимагый», «массакүләм» мәгънәсен белдерә торган кисәк. *Әгәр Мухинны чыгармасагыз, мин бу хәл турында Халык фронтына хәбәр итәчәкмен.* З.Зәйнуллин

**ХАЛЫ́КАРА** *с.* 1) Төрле дәүләтләр арасындагы сәясәткә, мөнәсәбәтләргә бәйле. *Без үзебезнең Конституциягә, халыкара кануннарга һәм, ниһаять, Русиянең үз Конституциясенә таянып, үзебезне якларга, хакыбызны дауларга тиешбез.* Т.Миңнуллин. *Халыкара хәлләр болганчык.* Г.Сафин

2) Күп халыклар, милләтләр яки аларның вәкилләре катнашында булган; интернациональ, бәйнәлмиләл. *1944 елда Ялтада һәм 1945 елда Германиядә уздырылган халыкара конференцияләргә генерал Антонов бик җентекләп әзерләнә.* З.Зәйнуллин. *«Бибинур»ны, Казандагы Мөселман киносы фестивalенә кадәр, Мәскәүгә 32 нче Халыкара кинофестивальгә чакырдылар.* Л.Әбүдәрова

**ХАЛЫ́К ИТҮ** *ф.* Ярату, барлыкка китерү, бар итү. *Әнә шулай һәрнәрсәне халык итүче Аллаһ сезнең раббыгыздыр, һәрнәрсәгә патшалык Аның кулындадыр ---.* Ф.Бәйрәмова

**ХАЛЫ́К КЫЛУ** *ф. к.* **халык итү**. *--- Нәүрүз көнендә Алла галәмне һәм Адәмне халык кылды, күктәге барча йолдызлар шул көннән башлап әйләнә башладылар, дигәннәр.* Г.Рәхим. *Мине игътибар кылыгыз, халык кылынганнан бирле варисларым өчен никадәр нәрсә җыйдым ---.* Ф.Яхин

**ХАЛЫКЛАШУ** *ф.* 1) Халык арасына киң таралу, халык күңеленә үтеп керү, үзләшеп китү, популярлашу (сүз, тәгъбир, җыр һ.б. тур.). *Кайчандыр талантлы шәхес тарафыннан тудырылган берәр образ яки канатлы сүз индивидуаль башлангычтан гомумилеккә күчә, ягъни гомумхалык кулланышына керә, халыклаша.* Р.Фәйзуллин. *Тулысынча халыклашкан хәлдә үзенең авторына – Сибгат Хәкимгә әйләнеп кайткан «Юксыну»ны, Әхмәт Фәйзинең вафатыннан соң җыр булып калыккан «Умырзая»ны искә төшерик.* М.Вәлиев

2) Халыкныкына якынаю, халыкныкы кебек булу; гадиләшү. *Мәгълүм булганча, татар совет драматургиясенең теле, бер яктан, шактый чарланды, гадиләште, халыклашты.* А.Әхмәдуллин. *Аерым алганда, хәзер шагыйрь сүзенең киң массаларга да барып җитүен теләп, шигырь телен халыклаштыруга, шул максатта аны җирле сөйләм теленә якынайтуга да игътибар арта.* Ф.Мусин

3) Халык кебек булу, халыкка якынаю, халык арасында күбрәк булу, аларның мәнфәгатьләрен аңлау. *Ләкин ул боларга карамый, ул, мин морзалыкны ташлыйм, мин халыклашам, дип хыяллана.* Г.Ибраһимов

**Халыклаша бару** Акрынлап халыклашу. *Грамматик мәсьәләләрнең шактый тирән тикшерелә баруына, атамаларның камилләшә һәм халыклаша баруына карамастан, бу грамматикаларда әдәби тел тирәсендә барган төрле агымнар көрәше дә киң чагылыш таба, гомумтөрки, төрек теле күренешләре дә урын ала.* В.Хаков

**Халыклаша башлау** Халыклашу билгеләре сизелү. *Ул иҗат иткән җырлар тиз арада халыклаша башлаган.* Р.Вәлиев

**Халыклашып бетү** Тәмам халыклашу. *«Раушаниям-бәгырем», «Утыр әле яннарыма», «Тамчылар тамар чаклар», «Күпме күзләр күреп онытылган», «Сөенечкә дисәм» кебек җырлар*

*күптән инде халыклашып бетте, буыннан буынга күчеп, халыкның үз җырларына әверелде.* Р.Миңнуллин. *Ул җырларның күбесе инде халыклашып беткән, әйтик, «Бала чагым чишмәләре», «Туган як моңы», «Бирешмә кайгыларга»* ---. Кызыл таң

**Халыклашып җитү** *к.* **халыклашып бетү**. *Болары – бар кешегә дә таныш, халыклашып җиткән мәкальләр.* В.Хаков

**Халыклашып китү** Кинәт халыклашу; билгеле моменттан алып халыклашу. *Халыклашып китү шулдыр – телгә керү.* Ш.Галиев. *Композиторның беренче әсәрләре үк бик тиз халыклашып китә: демонстрацияләрдә җырлана, концертларда башкарыла, урыс телендә башка милләт тыңлаучыларына да җиткерелә.* Т.Әйди

**ХАЛЫКЧА** *рәв.* Халыкта кабул ителгәнчә, халык кебек, халыкта булганча; гади итеп. *Мин әнинең бердәнбер баласы һәм юлдашы булганга, ул мине, халыкча әйткәндә, өрмәгән җиргә утыртмый – шул дәрәҗәдә якын һәм үз тота иде.* Г.Ибраһимов. *– Тычкан уты ич бу! – диде ул үз-үзенә, төнлә уттай ялтырый торган бу бәләкәй бөҗәкнең халыкча исемен хәтерләдә.* Г.Әпсәләмов

**ХАЛЫКЧАН** *с.* **1.** 1) Халык белән ныклы бәйләнештә булган. *Врач профессиясен ул иң тынгысыз, иң халыкчан профессия дип саный иде.* Г.Әпсәләмов

2) Халык рухына туры килә торган; киң массалар ярата торган. *Бу җәһәттән Илдар Юзине ул еллардагы иң халыкчан шагыйрь дип атап буладыр.* Р.Зәйдулла. *Әгәр сәнгатькәр үзен халыкның бер өлеше итеп тоя икән, аңа халыкчан булып кылануның кирәге юк.* А.Тимергалин

3) Халыкныкы кебек, халыкка туры килә, охшый торган; табигый; гади, үз. *Аның үзенә генә хас шигъри күзаллавы, образлар системасы, халыкчан җор үткен теле бар.* М.Шабаев. *Алтынчәч аңа гади һәм халыкчан, олы мәгънәле һәм бала чакта да, олыгайгач та килешә торган, матур яңгырашлы исем кушар – Газизә дип атар.* М.Маликова

**2.** *рәв. мәгъ.* Халыкка якын рәвештә; аңлаешлы итеп, табигыйга охшатып, гади итеп. *Әлбәттә, белгәнне язарга; әлбәттә, үзеңчә, шул ук вакытта кешеләргә дә ирешерлек – халыкчан итеп язарга тиешсең.* Р.Фәйзуллин. *Халыкчан язам дип, телне фәкыйрьләндерү, түбәнәйтү, ихтыярсыздан базар теленә әверелдерү куркынычы – байтагыбызга уртак кимчелек.* Р.Батулла

**ХАЛЫКЧАНЛЫК** *и.* Халыкчан булу. *Иҗатымның төп өлешен тәшкил иткән сыйфатларның берсе – халыкчанлык, дип саныйм.* Ф.Яруллин. *Шундый гадилеге, ягымлылыгы, халыкчанлыгы өстенә ул халык тормышын биш бармагы кебек белгән, җилкәсендә тау кадәрле энциклопедик белемнәр йөрткән зур галим дә иде.* Х.Миңнегулов

**ХАЛЫКЧЫ** *и. кит.* 1) Халык мәнфәгатьләрен яклаучы. *Мәгърифәтчеләрдән аеруча Каюм Насыйрины татарларны торгынлыктан уятучы, халыкны үз теленә, тарихына, мәдәниятенә таба юнәлтүче беренче халыкчы дип исәпләргә кирәк.* Р.Ганиева. *Ибраһимов иҗатында халык мәнфәгатьләрен кайгыртып йөрүче халыкчы образы киң чагылыш таба.* З.Сәлахова

2) *тар.* Народник, народниклык тарафдары. *Халыкчы, эсер, эсдек булып, үзара аз-маз бозылышып та алалар.* Г.Ибраһимов. --- *Гаяз Исхакый яшьлегендә социалист иде һәм гомеренең соңына кадәр халыкчы һәм социаль хокукны яклаучы идеалист бер кеше булып калды.* Казан утлары

**ХАЛЫКЧЫЛ** *с. иск.* **1.** *к.* **халыкчан 1.** *Мисраглардан һаман да шул халыкчыл, көчсезләрне яклаган батыр көрәшче Тукаемыз рухы аңкып тора.* Ш.Мөхәммәдьяров. *Тукай халыкчыл иде.* М.Вафа

**2.** *рәв. мәгъ. к.* **халыкчан 2**. --- *тәрҗемә практикасында кулланылган өченче принцип: халыкчыл уйлап, шул халыкның сүз сөрешенә, җөмлә төзелешенә туры китереп тәрҗемә итү.* Г.Хәбиб

**ХАЛЫКЧЫЛЫК** *и. тар.* Халыкчы (*2 мәгъ.*) булу; народниклык. *Романда XX гасыр башы Россия яшәешенең катлаулы, күпкырлы сурәте тудырыла: иҗтимагый-сәяси хәрәкәтләргә дә, милләтчелек, халыкчылык мәсьәләләренә дә, татарлардагы кадим һәм җәдит тартышларына да гомумиләштереп бәя бирелә.* Г.Ибраһимов. *Бу вакытта бигрәк тә руслардагы халыкчылык (народниклык) хәрәкәте, аның идеологиясе, шул идеологияне уздырган әсәрләр (шул исәптән Тургенев иҗаты) йогынтысында татар әдәбиятында да халык арасында аңлату алып барган разночинец образлары тудырыла.* Р.Рахман

**ХАМ** *и. яһүд сөйл. тирг.* Оятсыз, тупас кеше. *Ул нахал, ул хам түгел!* Р.Миңнуллин. *Син – надан, хам, оятсыз, имансыз һәм кансыз бер хайван.* З.Хәким

**ХАМЕЛЕО́Н** *и. гр.* 1) *зоол.* Кәлтәләр отрядыннан эссе якларда агач башларында яши һәм яктылыкка, тирәюньдәге төсләргә, төрле ярсытучыларга каршы тиресенең төсен үзгәртергә сәләтле кәлтәсыман сөйрәлүче хайван. *Хамелеон төсле һәр мизгелгә, шартка җайлашыр, төсен үзгәртү гадәте сизгер.* Г.Хөсәенов. *Бу отрядка кәлтәләр, агамалар, гекконнар, вараннар, хамелеоннар һәм еланнар керә.* Т.Шакирова

2) *күч. хурл.* Икейөзле, аумакай; урынына, шартына карап яисә үз файдасы өчен карашларын, фикерләрен тиз үзгәртә торган принципсыз кеше. *Ул – монафикъ, тыйнак булып кыланырга гына мөмкин, чөнки гадәттән тыш ялганчы, оста артист, хамелеон ул.* А.Тимергалин. *Аларга яраклашу өчен хамелеон булырга, барысына да: сулларга да, уңнарга да, неформалларга һәм милләтчеләргә дә, либералларга вә радикалларга да ярарга кирәк иде.* Р.Мирхәйдәров

**ХАМИ** *и. гар.* Төньяк Африкада телләре үзара якын булган тугандаш халыклар төркеме һәм шул халыкларның бер вәкиле; хамит. *Хами телләр*

**ХАМИЛӘ** *и. гар. иск.* **1.** Йөкле хатын. *Кырык яшьлек хамилә*

**2.** *с. мәгъ.* Йөкле, йөккә узган. *Анам аннан хамилә булды.* К.Насыйри. *Төшеңдә буйга узган хамилә хатынны күрсәң, улың туар, ди Мөхетдин бине Гарәби.* Ф.Яхин

**ХАМИТ** *и. фр. к.* **хами**

**ХАМСА** *и. гр. зоол. к.* **камса**. *Балык дигәч тә, Каспий хамсасы белән Балтыйк килкиен ашап утырмый инде.* А.Гыйләҗев. *Ул башта тирән итеп сулыш алды, өч-дүрт йотуда стаканны бушатты да койрыгыннан тотып хамса капты.* М.Юныс

**ХАН** *и. кыт. тар.* Төрки һәм монгол халыкларында феодаль идарәченең титулы; шул титулга ия булган зат. *– Миңа синең антларың да, тузан булуың да кирәкми, Тотыш углан, – диде хан, салкын гына.* Н.Фәттах. *– Хан җәмәгате булу өчен туган кыз иде Гәүһәршад, әллә нигә ашыкты, – диде.* М.Әмирханов

◊ **Хан заманындагы** *к.* **хан заманыннан калган**. *Югыйсә әнә теш врачлары, сыйфатлы снимок юк, дип зарлана, ә хирургия хан заманындагы кораллар белән эшли, алары да җитәрлек түгел.* З.Мурсиев. **Хан зама-**

**ныннан калган** Бик иске, күптәнге, әллә кайчангы; борынгы. *Кешелеккә киярргә бер матур костюмы бар барын, ләкин ансы да хан заманыннан калган, күптән модасы чыккан иде.* Х.Ибраһим. **Хан кызы** *хурл.* Үзен башкалардан өстен саный, әллә кемгә куя, иркә, көйсез, эш яратмый торган кызга карата әйтелә. *Нәрсә ул анда хан кызы булып, теге кирәк, бу кирәк дип кыланып ята.* Ф.Яруллин

**ХАНӘ** *и. фар.* Өй, йорт, бина. *Сабир исерек чакта әйткән, Зәйтүнә үз өендә әллә нинди ханә оештырып ята икән, дигән.* Р.Батулла. *Нәкъ сәгать өчтә керү ишеге буяулы тимер тышлы ханәнең чакыру төймәсенә бастылар.* Т.Галиуллин

**-ХАНӘ** Кушма сүзләрдә «бүлмә, йорт, бина» мәгънәсен белдерә торган икенче кисәк. *– Ләкин авылда китапханә булмагач, миңа бөтенләй диярлек укырга туры килмәде шул, – дип офтанып әйтеп куйды.* В.Нуруллин. *Әбекәй дип тә әйтергә булыр иде, ак халат бераз яшәртә бит ул, бу апа да авыр исле, авыр сулышлы хастаханә бүлмәсенә ниндидер яктылык, җиңеллек, хәтта өмет алып кергән кебек булды.* Г.Гыйльманов

**ХАНӘВЕЗ** *и. фар.* Ефәк тукыма төре. *Ханәвез (ханәwез), канәwез дип элек бик тыгыз, су үткәрми торган ефәк тукыманы атаганнар.* Р.Әхмәтьянов

**ХАНӘДАН** *и. фар. кит.* Династия; дәрәҗәле нәсел; тирән тамырлы, тарихта танылган асылзат кешегә таянган нәсел. *Безнең ошбу гасырыбызга кадәр Россия хөкемдарлары өч ханәданнан тора.* Ш.Мәрҗани

**ХАНӘКӘ** I *и. фар. тар.* 1) Суфи, дәрвишләрнең яшәү урыны, уку, гыйбадәт кылу, зикер кылу өчен шартлары булган бина; тәкия, тәккә. *Казан каласы кырындагы дәрвишләр Харәзем суфилары белән элемтәдә торалар, һәр шәһәрдә диярлек ханәкәләре бар, үзләренең мәчетләре.* М.Хәбибуллин

2) *к.* **тәкия** (*2 мәгъ.*). *Ә дөресе анын – ханәкә, ягъни, әйтик, хаҗга, табынырга килүче безнең ише дәрвишләргә җәйге торлау – икенче төрле әйткәндә – дөрбә.* Ә.Баян

**ХАНӘКӘ** II *и. монг. тар.* Хан нәселеннән булган хатын-кыз; хан кызы. *Юлда Казанга кайтучы ханәкәне (Касыйм хан хатыны – Ибраһим хан әнисе) очраталар.* М.Гайнетдин. *Тавис ераклашкач кына, падишаһ тезгенне бушатты, өйрәтелгән ат Сөем тутай янында – ханәкә ишеге турында туктады.* Р.Батулла

**ХАНӘШ** *и. тар.* Хан хатыны, ханча. *Ханына ханәш булып, Тиңенә тиңдәш булып, Киңәшкә киңәш булып Гомер кичә Нурсолтан.* С.Әхмәтҗанова

**ХАНБИКӘ** *и. тар.* 1) Хатын-кыз хан. *Моны ишеткәч, Сөембикә ханбикә болай дип әйткән, ди: – Әгәр татар бәкләренең барчасының авазы бер булса, Казан җиңелмәс иде.* Р.Мостафин. *Ханбикә, мәсәлән, улы Сәхибгәрәйне күз уңында тотып, Кәбирне үз даирәсенә якынлаштыруны кирәк санады.* М.Әмирханов

2) Хан хатыны, ханча. *Ханбикә Фатыймага нибары 17 яшь, кияүгә чыкканына өч ел икән.* М.Галиев. *Казанны алып, берсе хан, икенчесе ханбикә буласы килә, димәк.* Ф.Зариф

3) *күч.* Иң югары дәрәҗәдәге, иң хөрмәтле, танылган, югары үрләр яулаган хатын-кыз. *Көрәштән көрәшкә яшәү – Татарымның канында. Гапгади бер эшче кызы, Спортта ул – ханбикә.* С.Әхмәтҗанова

**ХАНДРА** *и. гр. сөйл.* Төшенкелек; пошаманга төшү, пошыну халәте. *Юк, чыннан да, хандра түгел иде бу, ә нәрсә беләндер көрәшергә омтылу, нәрсәгәдер һөҗүм итү һәм ниндидер яктылыкка табан ымсыну иде.* Г.Рәхим. *Улың да булгач, бирешмәскә, хандрадан мөмкин кадәр тиз котылырга кирәк.* А.Хәсәнов

**ХАНҖА** *и. гар.* Монафикъ, икейөзле кеше. *Әйе, карт анаңа инсафлылык, чын итагатьлелек күрсәтү урынына каты бәгырьле, кансыз-җансыз ханҗа булсаң, хакың бер тиен лә синең, адәм...* Э.Касыймов. *Бик тыкшына башласалар, җибәр син аларны ераккарак! Бетмәс монда ханҗалар.* М.Маликова

**ХАНЗАДӘ** *и. фар. тар.* Хан улы яки хан кызы. *Ханзадә гаҗәпләнүеннән авызын ачып, сихерләнгән кешедәй, кызга карап катып калган, дөньясын оныткан.* Р.Батулла. *Ул үзен ай битле чибәр кәләшен усал Дию пәрие тырнагыннан йолкып алган кыю ханзадә кебек хис итә иде.* М.Әмирханов

**ХАНИС** *и. гар. иск.* Антын бозучы, антында тормаучы; ялганчы. *Ашауэчүемез дә, мулла абзый, шуның кеби: атна буйлап кайнар аш күрмимез, каймак, май, йомырка дигән нәрсәнең ике ел буе төсен күргәнем юк, дип ант итсәм, мулла абзый, ханис булмам.* Г.Исхакый. *Алтынны да ул, йөздән ким булса алмыйм, дип ант итте, без, аны сынар өчен, туксан тугыз алтын санап алдына ыргыттык, ул аны алып, антына ханис булды.* Н.Исәнбәт

**ХАНЛЫК** *и. тар.* 1) Хан булу, хан дәрәҗәсе. *Минем углым ханлык таҗын киде – нигә чыгарасың исәптән?* З.Мансуров. *Нинди тәхет кабат, нинди ханлык?* В.Имамов

2) Хан идарә иткән дәүләт, ил; биләмә. *Дөрес, андый егетнең ханлык тәхетен тотуы шарт ителмәсә дә, әмма дә йөрәк тәхетенә менүе һичшиксез сорала иде.* Ф.Яхин. *[Нурсолтан] Кырык еллап гомерен фида кыла халкына, Мәскәү белән килешеп Тыныч яшәү хакына, Үз ханлыгын дәүләт итеп Саклап калу хакына.* С.Әхмәтҗанова

3) Ханлык (*2 мәгъ.*) белән идарә итү, хакимлек; шул хакимлек чоры. *Ханлык чорына багышлап тагын бер роман язарга уйласаң, ул исемнәргә яңадан әйләнеп кайтмыйча мөмкин түгел.* В.Имамов

**ХАНЛЫ́К ИТҮ** *ф.* Хан булып тору, хан вазифасын башкару. *Казанга соңгы килүендә ханлык итүе 14 ел, унөч яшендә кайта-килә Казан тәхетендә утырган елларының җәмгысы 22 ел булып, Җиһангир хан 40 яшендә вафат була.* М.Хәбибуллин. *Бату иксез-чиксез иле белән шул шәһәрдән торып ханлык итте.* Р.Зәйдулла

**ХАНЛЫ́К КЫЛУ** *ф. к.* **ханлык итү**. *Һади Атласи әйтүенчә, Габдулла хан «Алтмыш беренче баба, Болгарда илле ел ханлык кылган...»* Р.Батулла. *Ул күптән алар өстеннән ханлык кылырга кызыгып йөри иде ---.* Ф.Яхин

**ХАНТ** *и.* Фин-угор телләре төркеменә кергән телдә сөйләшкән, күпчелеге Ханты-Манси округында яшәгән халык атамасы һәм шул халыкның бер вәкиле. *Хәзерге вакытта Төньяк Боз океанына таба Иртеш буйларында хант һәм манси халыклары яши.* Ф.Яхин. *Болар, чыннан да, геолог Фёдор Чусовитин һәм үзенең хосусыйлаштырылган боланнары белән экспедициягә йөк ташырга ялланган хант кешесе Коля булып чыкты.* И.Хуҗин

**ХАНТЫ** *и. к.* **хант**. *Анда удмурт, башкорт, коми, пермяк, ханты, манси, ненец һәм кайбер башка әдәбиятлар бар.* Х.Миңнегулов. *Төрле ханты, манси, алеутлар белән кул биреп көрешеп йөрергә, аларның теге чум дигән куышларына кереп болан ите ашарга, төн*

*балыкны телемләп телеп, строганинадан авыз итәргә, кар өстенә җәелгән тиреләрдә аунап йокларга [иде].* К.Кара

**ХАНЧА** *и. монг. тар.* 1) Хан хатыны. *Тәкъдир кушып, әйе, ханча булгач, хөрлегемне мин дә югалттым.* З.Мансуров

2) Хатын-кыз хан, ханбикә. *Ак мангытлар ыруыннан Тимер бәкнең бүзедер, Бүз баласы – кызыдыр, Казан, Кырым ханбикәсе Нурсолтан ханча үзедер.* С.Әхмәтҗанова

**ХАНЫМ** *и.* 1) *тар.* Хан хатынының рәсми титулы һәм аңа мөрәҗәгать итү сүзе

2) Кияүгә чыккан хатын һәм шуңа мөрәҗәгать итү сүзе. *Кара аны, Разия ханым, бүген кешеләр алдына чыгасы булма!* К.Тинчурин. *– Миңә шулай, Миңсылу ханым, – диде ул тантана белән, – балаларның кайсын кая җибәрергә икәнен без синнән башка хәл итәрбез.* Ф.Яруллин

3) Таныш булмаган өлкәнрәк яшьтәге хатын-кызны атау һәм шуңа мөрәҗәгать итү сүзе. *Ханым дәшмәде, ни уйлагандыр, күз карашы усал, аяусыз иде.* А.Гыйләҗев. *Гафу итегез, ханым, әгәр хәтерем ялгышмаса, мин сезне кайдадыр күргән кебек тоелгандай итәм.* М.Кәбиров

**ХАНЫ́МӘФӘНДЕ** *и.* Ихтирам белән хатын-кызга мөрәҗәгать итү һәм аны атау сүзе. *– Тоз ваннасы икән бу, бик файдалы, ди ханымәфәнде, – дип, дәвалanучыдан уздырып, мактарга кереште фотограф.* Г.Гомәр. *Өйләнгән чактагы «мин сине ханымәфәнде дип йөртермен» дигән вәгъдәсе әллә кайчан онытылган иде.* А.Гыйләҗев

**ХАНЫШ** *и. тар.* Ханның кияүгә чыкмаган кызы, кайчагында ханбикә. *Сөйкемле ханыш*

**ХА́ОС** *и. гр.* 1) Борынгы грек мифологиясендә дөнья яратылганга кадәр вакыт; караңгылык һәм томаннан гыйбарәт оешмаган материя; беренчел дымлы караңгылык. *Төрле халыкларның бик борынгы мифларыннан билгеле булганча, кайчандыр Җиһанда гомуми тәртипсезлек – тәүге хаос хөкем сөргән, әле Ай, Кояш, йолдызлар да, Җир, кеше һ.б. да булмаган.* Ф.Урманче. *Кайбер мифологик күзаллауларда – дөнья илаһи көчкә ия зат тарафыннан, икенче берәүләрендә формасыз хаос һәм караңгылыкның үсеше нәтиҗәсендә яратылган дип уйлана.* Мифлар

2) Космогониядә материянең беренчел халәте; нәтиҗәдә аннан бөтен Галәм: йолдызлар, планеталар һәм башка күк җисемнәре барлыкка килгән. *Борынгы кеше галәм, хаос, җиһанны тудырган күк алласына буйсына, Тәңре кулында яши.* Г.Шәйхиева. *Борынгы төркиләр һәм шул исәптән болгарлар карашынча, хаос, ягъни буталчык, тәртипсез башлангычны чагылдырган иксез-чиксез су өермәсеннән дөнья, галәм барлыкка килә, хаос тәртипкә керә, пространство – Җир, Кояш, Ай ярала.* Фәнни Татарстан

3) Тәртипсезлек, чуалчыклык, буталчыклык. *Күз күреп ияләшмәгән бу күренештә бер карасаң – никадәрле хаос, ташлар чытырманлыгы; икенче карасаң – никадәр камиллек, җир белән күкләр тоташкан симфоник манзара, табигать гармониясе!* Р.Низамиев. *Һәркем үзе теләгәнчә яши башласа, хаос килеп чыгачак бит.* Р.Габделхакова

**ХАРА́КТЕР** *и. гр.* 1) Кешенең үзүзен тотышында чагыла торган аеруча тотрыклы төп психик үзенчәлекләр җыелмасы; холык, табигать. *«Һәркемдә характер төрлечә инде ул, аны үзгәртү кыен», – дип, үзен юата, уздырып җибәрә.* Н.Хәсәнов. *Бер бүлмәдә унике кыз: унике характер, унике гамәл.* Д.Каюмова

2) Ихтыяр, рухи ныклык; ихтыяр көче. *Рәхмәт, энем, синдә дә характер бар икән.* Н.Гыйматдинова

3) Предметның, физик яки психик күренешләрнең үзлеге, үзенчәлеге, төп сыйфатлары. *Шуңа күрә архитектор тирә-юньнең характерын, тигез яки таулы булуын истә тотып эш итә.* Ф.Хатипов. *Буяуларның төсе предметларның характерын чагылдырырга тиеш.* К.Гыйззәтов

4) Нәрсәнең дә булса эчтәлеге, асылы һәм үзенә генә хас билгеләре, сыйфатлары, үзенчәлекле ягы. *Әмма без заман герое хакында уйланганда үткән чорда язылган әсәрләргә мөрәҗәгать итәбез икән, иң беренче чиратта шул чорның үзенә бәя бирә белергә, шул чорның характерын истә тотарга тиешбез.* Н.Камал. *Бераз кырысрак, кискенрәк стиле әсәрнең характерына, эчтәлегенә туры килеп тора.* В.Имамов

5) *әд., сәнг.* Бер төр кешеләргә хас үзенчәлекләрне гомумиләштереп биргән образ, тип. *Әтулы канлы, катлаулы характер ярдәмендә драматизм тудыру – ул драматургия төренең реализм юлыннан алга хәрәкәт итүен күрсәтә торган яклардан берсе.* А.Әхмәдуллин. *Бүген ул комедия жанрында тулы канлы характер тудырса, мәзәкчән хәлләрне ихлас чарлавы белән тамашачы күңеленә хуш килсә, иртәгесен социаль драмалардагы геройларны психологик нәфислек кулланып, җан атып уйнавы белән тамашачыны үз артыннан ияртә.* Д.Гыймранова

**ХАРАКТЕРИ́СТИКА** *и. гр.* 1) Кемгә яки нәрсәгә дә булса хас сыйфатлар, үзенчәлекле яклар турында бәяләмә, тасвирлама. *Миркасыйм агага бернечә сүз белән генә характеристика бирергә кушсалар, мин: «Аның кулы каты, күңеле йомшак» – дияр идем.* Р.Вәлиев // Төрле хәл, күренеш, вакыйга, һ.б. турында әйтелгән (язылган) фикер. *– Хатын базарга китте, иртән ашыйсы килмәде, батареяларны начар җылыталар, баш авырта, – дип, ул бер җөмлә белән обстановкага характеристика бирде.* М.Мәһдиев

2) Кешенең хезмәте һәм җәмәгать эшчәнлеге турында рәсми рәвештә бирелә торган язма бәяләмә. *Тегеннән бик шәп характеристика белән кайткан Зәкәрҗанны бер көн эчендә директор иттеләр дә куйдылар.* М.Мәһдиев. *Аттестатың килгәнче, без монда сиңа хезмәтең турында характеристика язып куярбыз.* В.Нуруллин

3) *әд.* Матур әдәбиятта персонажга бирелә торган тасвирлама, сурәтләү. *Моннан да төгәл биография, моннан да төгәл психоанализ, моннан да дөрес характеристика, әлеге адәмнең моннан да төгәл портреты дөньяда булырга мөмкин түгел.* Г.Рәхим. *– Кайда калган идек әле? – дип сорадым, әдәби геройга характеристика бирү мәсьәләсен дәвам иттерергә теләп.* Ф.Яхин

4) *тех.* Нәрсәнең дә булса техник үзлекләре, сыйфатлары; шул сыйфатлар турындагы язу. *Аппаратның характеристикасы инглиз телендә язылган иде.* Ф.Абдуллин. *Ул иң элек телевизорның техник характеристикасын укып чыкты.* Р.Вәлиев

**ХАРА́КТЕРЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **характерлау**. *Шуның белән бергә ул шәхес буларак та характерлана.* Р.Зарипова. *Әлеге образ уңай яктан гына характерланган дияргә дә мөмкин.* Н.Юсупова

2) Үзенә генә хас билгеләре булу; нинди дә булса үзенчәлекләре белән аерылып тору. *Әбүгенге көн, бүгенге заман нindидер бер көчләрнең кеше күңеленең өрфия кебек нечкә оят пәрдәсен ертып, болгап-болгап пычракка атмак-*

*чы теләкләре белән характерлана бугай.* Б.Рәхимова. *Гыйсъянчылык, иң беренче чиратта, яшәеш кануннарына, шул исәптән дин-шәригать кагыйдәләренә, җир тормышындагы гаделсезлекләргә, кешедәге караңгы якларга каршы чыккан бунтарь, гыйсъянчы герой үзәккә куелу белән характерлана.* Д.Заһидуллина

**Характерлана башлау** Характерланырга тотыну. *1950 еллардан башлап, тарихи проза күп тармакларга бүленеп үскән, эчтәлек һәм тема ягыннан киңәя барган әдәби юнәлеш буларак характерлана башлый.* З.Шәйхелисламов

**Характерланып килү** Озак вакыт дәвамында характерлану

**ХАРА́КТЕРЛАУ** *ф.* 1) Кемнең яки нәрсәнең дә булса үзенә генә хас билгеләрен, үзенчәлекләрен, сыйфатларын күрсәтү, характеристика бирү. *Бу факт, әлбәттә, Мөнирне уңай яктан характерлый, аның олы җанлы булуын күрсәтә.* Ф.Хатыйпов. *Шулар арасыннан әдәбият тарихы, тарих материалларына нигезләнеп, чын татар зыялыларын аерып алып характерлый.* Фән һәм тел

2) Сурәтләү, тасвирлау. *Яки «Кәләпүшче кыз» хикәясендәге Кәримәнең икенче ирен әдип түбәндәгечә характерлый: «Җыйнак кына, сак кына, ашамы-эчеме яхшы гына тереклек итә торган кеше».* Г.Зиннәтуллина. *«Матур» сыйфаты аша аның тавышын характерлый, йөз матурлыгын – «чибәр» сүзе, гомумән тышкы кыяфәтен – «күркәм» сүзе аша сурәтли.* З.Әхәтова

**Характерлап алу** Тиз генә характерлау

**Характерлап бару** Һәрберсен, булган берсен, рәттән барысын да характерлау. *Кызларның сәхнәгә чыккан берен Миләүшә гороскоп буенча характерлап барды.* Т.Нәҗмиев

**Характерлап бетерү** Тулысынча характерлау; барысын да характерлау. *Нәкъ сезнең хакта әйтелгән кебек, ләкин, никадәр матур яңгырамасын, ул сезне тулысынча характерлап бетерә алмый.* Р.Мирхәйдәров

**Характерлап бирү** Тулысынча, бөтен ягын характерлау. *Матур әдәбиятның чагылдыру чараларын характерлап бирегез.* К.Гыйззәтов. *Бу сүзнең лексик кабатлануы кызның тышкы кыяфәтенә игътибарны юнәлтә, аның психологик халәтен характерлап бирә.* Фәнни Татарстан

**Характерлап карау** Характерларга тырышу, характерларга омтылу. *Шигырьнең үзенчәлекле чишелешен характерлап карагыз.* Әдәбият

**Характерлап китү** Бик аз гына яки сөйләм барышында характерлау; тиз арада характерлау

**Характерлап тору** Гел характерлау, даими характерлау. *Бу хәл (хәзерге күзлектән караганда гап-гади таләп) үзе һәм аңа булган реакция шул заман иҗтимагый тормышын характерлап торган бер күренеш иде.* Р.Фәйзуллин

**Характерлап узу** Берәр эш яки сүз барышы уңаеннан характерлау

**Характерлап үтү** Эш яки сүз уңаеннан характерлау. *Директорыбыз аны бик җаваплы административ хезмәткәр буларак характерлап үтте.* Кызыл таң

**Характерлап чыгу** Рәттән барысын да характерлау. *Абсатый, бабасы әманәтенчә, һәрберсен кыскача характерлап чыкты.* С.Шәрипов

**Характерлый башлау** Характерларга тотыну. *Килеп утыруга ук ул ирен характерлый башлады.* Р.Вәлиев

**Характерлый төшү** Тагын да бераз характерлау. – *Әлеге персонажны тагын бераз характерлый төшәргә кирәк булыр, – дип дәвам итте укытучы сүзен.* М.Вәлиев

**ХАРА́КТЕРЛЫ** *с.* **1.** 1) Үзенчәлекле, үзенә бер төрле, башкалардан аерылып торган, үзенә хас аерым сыйфатлары булган. *Нурия күп уйный һәм күбрәк характерлы рольләрдә чыгыш ясый.* Д.Гыймранова. *Тик аларны таный белергә, иң характерлы, гыйбрәтле якларын тотып, җәмгыятьнең алга барышына комачаулаучы көч икәнлекләрен фаш итеп, көлдерә белергә кирәк.* Р.Фәйзуллин

2) Кемнең яки нәрсәнең дә булса үзенә генә хас булган. *Чөнки ул чакта, фашизмны җиңү өчен, һәр халыкның үз арасыннан чыккан, шул халыкның характерлы сыйфатларын яхшы белгән командирлар кирәк иде.* Ф.Яруллин. *Үзаң ул – үз шәхесеңнең асылын, үзеңнең характерлы сыйфатларыңны, тормыштагы, җәмгыятьтәге үз ролеңне ачык аңлау хәле.* Ф.Зариф

**2.** *хәб. функ.* Үзенчәлекле булу. *Шунысы характерлы, татар театрында андый әсәрләр зур уңыш казана.* А.Әхмәдуллин. *Бу дәвер – Ш.Камалның зур иҗади активлыгы белән характерлы.* Мәйдан

**ХАРАКТЕРСЫЗ** *с.* Ихтыяр көче җитмәгән, чит йогынтыга бирелә торган. *Нәрсә, мине характерсыз, пешмәгән кешегә саный әллә?* Ф.Яхин. *Ә ул үзе көчсез, характерсыз, җегәрсез икән...* Х.Ширмән

**ХАРА́КТЕРСЫЗЛЫК** *и.* Чит йогынтыга тиз бирелүчәнлек, йомшак холыклылык; аумакай булу. *Төшкә ышану – характерсызлык ла ул.* Н.Исәнбәт

**ХАРАМ** *и. гар.* **1.** *дини* Дин тарафыннан катгый тыелган, үтәлгәне, эшләнгәне өчен җәзага тартылу тиеш булган, инкяр ителгәне өчен диннән чыгара торган эш, гамәл h.б. *[Гасыйм Саләхов] Харамга кермәгән, ялтыравыклы әйберләргә кызыкмаган, алгы планга чәчрәп чыкмаган.* Ф.Галимуллин. *Вәгъдәңне боздың икән, димәк, харамга таба атлап киттең дигән сүз була, һәм, китапларда шулай күрсәтелер, харам эшләгән кеше тәмуг утында яначак.* Ф.Яхин

**2.** *с. мәгъ. дини* 1) Дин тарафыннан катгый тыелган, хәләл булмаган. *Харам юл белән кергән мал мантымый.* Р.Батулла. *Димәк, аның бу харам эше эзсез, шома гына узды.* Р.Мулланурова

2) *күч.* Канунсыз, рөхсәт ителмәгән юллар белән табылган, кулга төшерелгән. *Моның өчен алдау һәм талау юлы белән хосусый кулларга күчкән ил байлыгын, читкә озатылган харам акчаларны кире дәүләткә кайтару мәсьәләсе хәл ителергә тиеш.* Ә.Еники. *Харам малның очы барыбер төртеп чыгасын уйламыйсыз...* М.Маликова

**3.** *рәв. мәгъ.* Алдашып, ялган белән; хакы булмыйча, хаксыз рәвештә; тыелган булып. *Бер денсезе, ялган вәгазь сөйләп, Кеше ризыгын харам ашады.* М.Шиһапов. *Әмма шәригатьтә бу мәсьәлә катлаулылардан санала: нәселдә бер-берсенә никахта харам саналып, сөт карендәшлек сәбәпле дә кешеләр үзара хәрәм булалар, әмма кайбер нәселләрдә катнашуда хәрәм саналса да, ризык аркасында гына хәрәм дә саналмаска мөмкиннәр.* Ф.Яхин. *Кемгәдер ул харам күренә...* Ф.Дәүләтгәрәева

**4.** *хәб. функ.* 1) Дин тарафыннан тыелу хәле. *Дуңгыз ите – аларда борынборыннан көндәлек милли ризык, ә ат – ят хайван, шуңа күрә ите дә харам.* З.Мифтахов. *Аның бу фикере «кыз балаларга гыйлем өйрәтү – харам» дип лаф оручыларга җавап булып яңгырый.* Т.Биктимерова

2) «Артык», «тиеш түгел», «килешми» дигән мәгънәдә. *Андыйларга Кеше дигән исем харам.* Н.Сафина. *Сине ятларга бирсәм, Сөләйман малае исеме харам миңа!* Н.Гыйматдинова

◊ **Харам ашау** Хакы булмый торып нинди дә булса акчаны тоту, нindiдер малдан файдалану. *Бәндәләр харам ашаудан, ятим өлешен алудан тыелмый, оят белми.* Р.Мулланурова. *Харам ашап, яңа гөнаһлар өстисе юк.* Д.Йосыпова. **Харам булсын** «Яхшылыгын күрмәсен, файдасы тимәсен» мәгънәсендәге бәддога сүзе. *Алар – көйсез кияүләр – бер генә җире ошамаса, бер нәрсәгә кәефләре китсә, хәзер киреләнәләр, бер тиенем харам булсын дип, тәртә җимереп качарга торалар.* Г.Ибраһимов. *Әгәр бүген дә бармасам, нәселем корысын, әткәм кушкан Сәгыйть исеме миңа харам булсын!* А.Гыйләҗев

**ХАРАМЗАДӘ** *и. гар. фар.* 1) Никахсыз ата-анадан туган бала. *Ул хәрамзадә инсафсыз углыңнан кич, аннан изгелек күрмәссең.* К.Насыйри

2) Нәселсез, әхлаксыз кеше, харам ашаучы

**ХАРАМЛЫК** *и.* Харам булу. *Хәзрәт бу юлда да, җыр һәм музыканың харамлыгын бөтенләй онытып, яулыгын чыгарып селтәп, әйләнгәләп биегән сымак итәргә тотынды.* Ф.Әмирхан. *Безды күңелне авыр сүз баягы, Кизәнде һәм сукты сукырлар таягы, Чакты, тешләшеп, харамлык чаяны, Изелде җан, сүнде...* Ф.Яхин

**ХАРАП** *с. гар.* **1.** 1) Куркыныч, коточкыч, бик начар. *Берзаманны әйләнеп баккан идем артка таба: Аһ, харап эш! Су анасы да минем арттан чаба.* Г.Тукай

2) *сөйл.* Сыйфатлар янында килеп, артыклык дәрәҗәсен белдерә: бик яман. *Иярgә мен дисә, туган аталарын да танырга теләмичә, харап эре булып кыланалар.* В.Имамов. *– Рәхмәт, инәкәй! – дип, әнинең кайтып кергәне ишетелеп кала, «мунча харап шәп булган, әби, йөз яшә» дип, әти кайта.* Д.Булатова

**2.** *рәв. мәгъ. сөйл.* Бик, искиткеч; бик каты, бик нык. Карабодай быел тирәякта бик харап уңды. Г.Ибраһимов

**3.** *ы. сөйл.* Бераз үпкәләү, гаҗәпләнү, киная яки ис китмәүне, иронияне белдерә. *– Харап, бер шалкан, бер өшегән бәрәңге әҗәл даруы санала икән, – диде Гайнан, бөтенләй гамьсез кеше кебек.* Г.Әпсәләмов. *Гыйльми түти, аңа суларга да ирек бирмичә, яңадан элеп алып китте: – Харап икән!.. Уйнышлар да җырлыйлар икән! Шуның өчен дә яшьләр ич алар!* Г.Бәширов

**4.** *хәб. функ.* Куркыныч, коточкыч, бик начар; җимергеч. *Эләктерә калса, эш харап!* А.Хәсәнов. *Артык тавышланмыйча гына (укытучылар сизсә – харап!) мин уйныйм, тегеләр җырлый башлады.* В.Нуруллин

**ХАРА́П БУЛУ** *ф.* 1) Җимерелү, бозылу, яраксыз хәлгә килү, юкка чыгу, ишелү (бина, корылма, машина һ.б.ш.). *Юлда нәрсәдер килеп чыгып, барысы да харап була – челпәрәмә килеп ваклаyып бетә.* К.Җәмит

2) Бәхетсезлеккә юлыгу, бәла-казага тару, берәр күңелсезлеккә дучар булу, начар хәлгә очрау. *Харап булдык бар малны юк итеп, Хәерчегә кердек әҗәткә...* А.Хәлим. *Соңарганчы, харап булганчы, безгә бу аланнан һич кичекмичә качарга кирәк.* А.Хәсәнов

3) Һәлак булу; үлү. *Илең өчен түгел, кемнәр өчен Харап булып кайттың табутта?* И.Юзеев. *Юк, бу югалту сугышта харап булган бихисап солдатларның берсе үлеме генә түгел иде, ә халкыбыз – татар халкы – үзенең иң асыл, садә күңелле улын, кабатланмас шәхесен югалтты.* З.Мурсиев

4) Тормышка ашмау, челпәрәмә килү (эш, план һ.б.). *Бруно шулай диде, ә үзе, әгәр, хәзер алып кил, дисә, бөтен эшнең харап булуы турында уйлап алды.* Г.Әпсәләмов. *Замполитка яисә секретлар бүлегеннән берәрсенә җиткерсәләр – эш харап булачак.* Р.Мөхәммәдиев

**ХАРА́П ИТҮ** *ф.* 1) Вату, җимерү, юкка чыгару, хәрабә хәленә төшерү. *Монда Атлантиданы харап иткән бер көнлек һәлакәткә мөрәҗәгать итүнең кирәге юк.* А.Тимергалин

2) Үтерү; һәлак итү. *Никадәр гөнаһсыз җаннарны харап иттең...* Г.Галиева. *Атаңны да шулар харап иткәндер әле, мәрхүмкәемне.* Г.Гыйльманов

3) Җәфалау, газаплау, интектереп бетерү. *Ә инде олы маллар тарафыннан таптап-сытып харап ителгән колын белән бозауларны санап бетермәле түгел.* В.Имамов. *Мине дә, үзеңне дә харап итәсең югыйсә.* Г.Тарханова

4) Бәхетсезлеккә төшерү, бәла-казага дучар итү. *Яңа гына яңгыр явып узган, юл юеш, һәм шул харап итте дә.* З.Зәйнуллин. *Марусяның бозымы харап итте аны, Марусяның бозымы.* Д.Салихов

5) Юкка чыгару, җимерү, бозу (эш, план һ.б.ш.). *Бер секунд, бары тик бер секунд кына харап итте бөтен эшне!* В.Нуруллин

6) Көчләү, мәсхәрәләү. *«Сихерче хатынны куркытабыз гына, куркытып акылга утыртабыз», – дип сүз биргән һәм Майяны харап иткән исерек ирләрне үзе өзгәләп ташларга әзер иде Нәфисә.* Г.Гыйльманов. *– Кызыңның пешеп килгән чагы, алай-болай харап итеп ташласалар, гаепне үзеңнән эзлә, – дидем.* А.Әхмәтгалиева

**ХАРИ́ЗМА** *и. гр.* 1) Кешенең үзенә карату, тартып тору, җәлеп итү, магнетизм сәләте. *Харизмага ия шәхеснең гәүдәсе яки йөзе дә балкый, ягъни нур сибә, ул эчтән яктыра.* А.Шәйхуллов. *Динарда эчке бер харизма бар, ул – үзенә җәлеп итә торган, итагатьле егет.* Көмеш кыңгырау

2) Талантлы, зур уңышка ирешкән, дәрәҗәле кешеләрнең башкаларны үзенә карата, сокландыра, ихтыярына буйсындыра белүенә нигезләнгән зур авторитеты. *Харизма, җылылык, тавыш – барысы да бар Салаватта.* Сөембикә. *Шуңа игътибар иттем: спортчыларның, бию хәрәкәтләрен дөрес башкарудан тыш, башкалардан аерылып торган костюм, макияж һәм харизма булуы да шарт.* Шәһри Казан

3) *сөйл. кимс. ялг.* Әрсезлек, башкаларга ошар өчен махсус тырышып кылану, артистлану, билгеле бер үзенчәлеге белән җәлеп итәргә тырышу күренеше. *Бүген маймыллану – шамакайлану (заманча тел белән әйткәндә – харизма) алдан йөри.* Г.Җәлилова. *Әллә анда әрсезлеге – харизмасы булган һәркем менә аламы?* Шәһри Казан

**ХАРИ́ЗМАЛЫ** *с.* Харизмасы булган; үзенә тартып, җәлеп итеп торган. *Ә Дилбәр апа кебек харизмалы һәм холкы җете кызыл төсләргә бай ханымны, режиссёр булсам, мин дә төп героиня итеп сайлар идем.* Әлмәт таңнары. *Ходайдан бирелгән тавышлы, харизмалы, үзенчәлеге булган җырчылар бик күп.* Безнең гәҗит

**ХАРИ́ЗМАЛЫЛЫК** *и.* Харизмалы булу; башкаларны үзенә тартып тора торган сөйкемлелек; лидерлык. *Монда харизмалылык бик зур роль уйный.* Идел

**ХАРИЗМА́ТИК** *с.* 1) Харизмасы булган, харизмалы. *Безнеке кебек шактый таркау, үз-үзен ихтирам итеп бетермәгән милләтне бары тик лидер – абруйлы, фидакяр, харизматик шәхес кенә берләштерә, күтәрә, коткара алачак, миңа калса.* Н.Шәрифуллин. *Ә президент имиджына туры килүкилмәвенә нәтиҗә ясасак, Рөстәм Миңнеханов сәясәт өлкәсендәге Америка белгече Д.Уитнцер язган кысаларга*

*туры килә: ул – харизматик, хәрәкәтчән, җитез, эчкерсез, нык һәм үз-үзенә ышана торган шәхес.* Татар заманы

2) Харизмага бәйле; харизмага нигезләнгән. *Идарәнең харизматик тибы – соңгы берничә дистә елда гына өйрәнелә башланган өлкә.* А.Шәйхуллов

**ХАРИКЫЛЬГАДӘ** *с. гар. кит.* Гадәттән тыш; гайре табигый, фәукыльгадә. *Болай, ничек тә булса, мәсәлән, юлдан зур акча табып, я бүтәнчә, ничек тә харикыльгадә бер эш белән байыйсы килә, шуңа ышанып, үзен үзе юата иде.* К.Тинчурин. *Бүген без харикыльгадә бер куркыныч мохиттә калдык.* Р.Батулла

**ХАРИТА** *и. гар.* Географик карта. *Тәрәзә аша, югарыда, Кырым күгенең нәкъ шушы көнбагыш чәчкәседәй эре йолдызлары, берсе икенчесенә алтын җеп сузып, галәм харитасын чигә иде.* А.Хәлим. *Менә монда (инструментлар сумкасын күрсәтә) бик кирәкле харита белән документлар, аларны сакларга кирәк.* Г.Каюмов

**ХА́РТИЯ** *и. гр.* 1) Нәрсә дә булса язылган пергамент, папирус бите, язу кәгазе; гомумән борынгы кулъязма, документ // Урта гасырларда: нинди дә булса хокуклар, ирек бирә һәм шуны раслый торган документ, грамота

2) Иҗтимагый-сәяси әһәмияте булган документ, декларация; килешү, шартнамә. *Әгәр ул Хартия гамәлгә керсә, без телләрне халыкара таләпләр, Европа стандартлары буенча үстерергә тиеш булачакбыз.* Р.Вәлиев. *Хартия проектын тикшерү барышында аның текстына башка сайтлардан материалларны күчереп алганда авторлык хокуклары турындагы закон үтәлергә тиешлеге турындагы пункт өстәлгән иде.* Кызыл таң

**ХАРЧЕ́ВНЯ** *и. рус* 1) *иск.* Арзанлы кабак, трактир. *Без харчевня хуҗасын чакырып алдык та, нигә аларны кыйныйлар, әйбер урлаганнармы, дип сорадык.* Т.Гыйззәт. *Бер дә булмаса харчевняга барып эчәрмен.* Г.Камал

2) Гади һәм арзанлы кабымлыклар, ризыклар тәкъдим ителә торган ашханә, кафе. *Кеп-кечкенә авылда соңрак өч харчевня, ике кабак ачылу да шушы станциягә, юл йөрүчеләрнең күплегенә бәйледер.* Р.Шәрәфиев. *Мирсәет пошаманга төште: әңгәмәдәше үз-үзен белмәс хәлгә якынлаша, бөтен харчевняны яңгыратып кычкырып сөйләшә.* Р.Мөхәммәдиев

**ХАРЧО** *и. груз.* Кавказ халыкларында: сыер ите белән ярма салып пешерелә торган шулпалы аш төре. *Балаларга тамак ялгар өчен ташбака шулпасы, харчо, украинча борщ һәм шампиньонлы аш тәкъдим ителә иде.* Ф.Латыйфи. *Яшәр өчен тулай торак бар, урын-җир бирәләр. Ашарга харчо, ботка, чәй...* Ф.Зыятдинов

**ХАС** *с. гар.* **1.** Кемдә яки нәрсәдә була торган, кем яки нәрсә өчен характерлы. *Берсеннән-берсе риза булып, яратышып, яшьлеккә генә хас ваемсызлык, куаныч белән, юктан да тәм, ямь табып яшәделәр.* А.Гыйләҗев. *Минминлекне, һаваланунны белми торган кешеләргә генә хас булганча, кирәксәкирәкмәсә дә гел елмаеп тора.* В.Имамов

**2.** *кис. мәгъ.* 1) Махсус, атап. [*Галиәкбәр:] Хас синең өчен заказ биреп эшләттем. «Казан» торты, – диде, карлыгып киткән тавыш белән.* А.Расих. *Хас аның өчен билгеләнгән аерым бүлмә дә бар иде.* З.Рәсүлева

2) *сөйл.* Нәкъ, төп-төгәл; ачыктан-ачык. *– Башыңа яулык ябынып, төреп кә дә капсаң, хас минем анай буласың, – диде Изерге.* З.Мурсиев

**ХАСИД** *и. гар. иск.* Көнче, көнләшүче зат. *Ул хасид әйтте: «Хәлифә аны белмәс, син бер җирдә яшеренеп тор, мин барып киләем, никадәр алганымны әйтермен», – дип, комсызланып, бик тә үтенеп, хатны алды.* К.Насыйри. *Бу эшне бертөрле дөнья күрмәгән надannар, хасидләр, бәлки, хирыслыктан, диерләр.* Г.Камал

**ХАСИЛ** *и. гар.* **1.** *иск.* Нәтиҗә. *Хасил: татар шигыре мәйданында Тукаев исә, тасвирымыз мәйданында иң гали ноктада Гаяз әфәндедер.* Г.Ибраһимов

**2.** *хәб. функ.* Барлыкка килү, бар булу, тормышка ашу; гыйбарәт. *Яр тулысынча ак ташлардан хасил, шуңадырмы, елга өсте учак яккан шикелле гел яктырып тора.* В.Имамов. *Нурдан хасил ул нәфис зат кул җитмәс, юк, күз карашы, уй көче җитмәстәй биеклектә, аның бер күз сирпүе сине парә-парә өзгәли, аның бер елмаюы сине лачын итеп күккә чөя, балдан татлы тавышы сине мәңгелеккә әсир итә...* Д.Булатова

**ХАСИ́Л БУЛУ** *ф.* Барлыкка килү, пәйда булу. *Ә гасырлар буе тупланган тормыш тәҗрибәсеннән, шуның эчендә туган рухи хәзинәдән бер селтәнүдә баш кактыңмы – күңелдә шәрә бушлык хасил буласын көт тә тор!* Ә.Рәшит. *Юктан бернәрсә дә хасил булмый.* Р.Фәйзуллин

**ХАСИ́Л ИТҮ** *ф.* Барлыкка китерү, оештыру, булдыру; тәшкил итү. *Аларның кайберләре түбәндәгеләр: Шалтырама чишмәсе Чуаш Иле суын хасил итә, Шайтанлы бай чишмәсе Шалтырама суына килеп кушыла.* Х.Садри. *Җылы булу фарыз түгел, фарыз түгел. Якты аша Җылылыкны күрсәтә алсам, Канәгатьлек хасил итәр Минем күңел.* Р.Харис

**ХАСИ́Л КЫЛУ** *ф. к.* **хасил итү**. *Дөнья шигъриятендә алар бөек җаннарның бер-берсенә аваз бирүен хасил кыла.* Н.Хисамов. *Хасил кылдың бу дөньяны Гөнаһың бөртегеннән!* Ф.Яхин

**ХАСИЯТ** *и. гар.* 1) Үзенчәлек, үзлек; кем яки нәрсәнең дә булса үзенә генә хас сыйфат. *Шунысын да искәртеп үтәсе килә: шигырьне уртага алып, аның тышкы һәм эчке хасиятләре турында сөйләшәсе урында, бездә, нишләптер, кайчак ике генә нәрсәгә игътибар итү бер модага кереп китте кебек.* Б.Рәхимова. *Аннан соң тагын да катлаулырак мәсьәлә – пациентның психикасында булган зарарлы хасиятләрдән (багланышлардан, гадәтләрдән) арыну максаты куела.* А.Тимергалин

2) Файда, уңай як, өстенлек; мәгънә, әһәмиятлелек. *Мунча ягуның эчке тәртибен, нечкәлекләрен, миллекләрнең шифасын, хасиятләрен бөтен ваклыкларына тиклем белә ---.* А.Гыйләҗев. *Карт, үз күңеленең иң тирән чоңгылларына төшеп, бу галәмәт күренешнең серле хасиятләрен ачыклап тормады, Ходай мәрхәмәте белән эләккән балыкны сулы чиләгенә салып, кармакларына яңа җим эләргә тотынды.* Г.Гыйльманов

**ХАСИЯТЛӘНҮ** *ф.* 1) Җиренә җиткереп, җентекләп, ипләп, җайлап эшләү, башкару. *Авторның һәр сүзе мәгънәле, тирән, аскорма белән каймаланган, хасиятләнгән.* Б.Рәхимова. *Әле яңа тәпи йөри башлаган, күрәсең, тырышып, хасиятләнеп атлый.* В.Нуруллин

2) Өметләнү, ниятләү, уйлау, тырышу. *Тәүгиз, һаман әтисенең ялгышын тотарга хасиятләнеп, сорау бирде.* Х.Камалов

3) *сөйл.* Канәгатьләнү, юану, күңелен күтәрү; рухи азык алу. *Ул, күрәмсең, бераз хасиятләнеп тә маташа бугай...* Ш.Камал. *Алар минем вәгазьләрне тыңлап, шуның белән хасиятләнеп яши.* Акчарлак

**Хасиятләнеп тору** Озак вакыт дәвамында хасиятләнү. *Син күрдеңме әле, әнә сул як почмакта, хатын-кызлар*

*арасында, кызыл шарфлы, матур гына, тәкәгә охшаган тәбәнәгрәк бер кыз хасиятләнеп торды.* Ш.Камал

**ХАСИЯТЛӘП** *рәв.* 1) Кадерләп, саклап, пөхтәләп. *Бер конфеты белән печеньесен ашаганнан соң, калганнарын хасиятләп кесәсенә салып куйды.* Г.Галиева. *Эшенә чумган Гөлшат Фаиковнаның елмайган йөзе, улыннан калган, Биби Шәрифәсеннән өрфия яулык бәрабәренә юдыртылган, хасиятләп илткән бетеш киемнәре күз алдыннан берәмберәм йөгерешеп үттеләр.* Ф.Яхин

2) Ипләп, җайлап, ашыкмыйча, яратып, эшнең тәмен табып. *Эштә кешенең характеры ачыла: бу агай иртә таңнан торып әкрен генә, салмак кына, хасиятләп эшли.* Ш.Галиев. *Ишегалдымдагы бакчама бәрәңге «падишаһ»ны да бик хасиятләп, җаен белеп, көлен сибеп утыртам.* А.Хәсәнов

**ХАСИЯТЛӘҮ** *ф.* Бик яратып, тырышып, җиренә җиткереп эшләү; нәрсәгә дә булса сакчыл мөнәсәбәттә булу, кадерләү, саклау. *Кемдер күпме хасиятләп тә үстерә алмый, ә ул орлыкларны кая төртеп куйса, шунда үсеп чыга.* Р.Исмәгыйлева. *Күрә идем бит инде, әни, «әти юлына» ничек карап торганыңны, ул утырткан алма бакчасын ничек хасиятләвеңне.* Татарстан яшьләре

**ХАСИЯТЛЕ** *с.* 1) Игелекле, шифалы, файдалы; бәхет китерә торган; изге. *Госман, Маньчжурия кырларында атакага ташланганда, иң хасиятле коткаручысы итеп Машаның бердәнбер бүләгеп – чиккән яулыкны саклады.* И.Салахов. *Шуңа күрә ул Билаллар йортындагы иң якты тәрәзә булып, бөтен тирә-якка әллә нинди үзгә бер хасиятле нур сибеп тора.* М.Вәлиев

2) Булдыклы, җиренә җиткереп эшли торган. *Фермада эшли башлавының беренче көннәреннән үк үзен тырыш, хасиятле терлекче итеп таныта, колхозның һәм районның иң нәтиҗәле эшләүче, иң алдынгы терлекчеләре сафына баса.* Г.Мөхәммәтшин. *Чыннан да тәбәнәк буйлы Сабир абзый һәм аның күгәрчен тиклем генә карчыгы Кәшифә апай – икесе дә бик эшчән, хасиятле кешеләр, җыйнак кына йортлары янында бик куе итеп чия куаклары үстерделәр.* Р.Фәизов

3) Җыйнак; әйбернең кадерен белә торган, тәртипләп куярга ярата торган; саклап, пөхтәләп, түкми-чәчми тота торган. *Бишекне өстән үк урап ябып куя торган юка каплавычын сандыгыннан эзләп тапты – хасиятленең хасиятлесе инде.* Г.Галиева

4) Киңкырлы, күпкырлы, бәрәкәтле. *Әйе, мишәр татарларының халык иҗатына күз салсаң, ул бик хасиятле.* Э.Каюмова. *Язучының хасиятле каләме безнең алга иҗатының чираттагы этабы булган китабын ачып салды.* Мәдәни җомга

**ХАСЛА́У** *ф.* Багышлау, атау, билгеләү; махсус эшләү. *Ходай сине минем өчен хаслап үстергән.* Х.Булатова. *Берсе – яшел чәйнең, берсе – кара, – Син салгансың ансын миңа хаслап.* Р.Рахман

**ХАССЫНУ** *ф. сир. к.* **хөсетләнү**. *Тик шайтаннарның миңа хассынуы моның белән генә бетмәгән икән әле.* Ш.Маннапов. *Илемә, җиремә ят куллар хассына.* Р.Ханнанов

**ХАСТА** *и. фар. сөйл.* **1.** 1) Чир, авыру, сырхау. *Хатында – тамак хастасы, пүчтәк кенә дару табар хәл юк.* А.Гыйләҗев. *Малайда ул заманнар өчен иң хәтәр хасталарның берсе – туберкулёз башланган була.* А.Тимергалин

2) Авырган кеше, авыручы. *Шул бер ягы бар инде: хасталар арасында айкалып кайткач, яшәүнең кадерен ныграк белә башлыйсың.* М.Маликова. *Элеккерәк елларда төрле үлән җыеп, хасталарны озын кыш буена им-том итеп йөргән карт-карчыклар шулай сөйләделәр.* В.Имамов

**2.** *с. мәгъ.* Чирле, авыру; авырый торган, авыру хәлендәге. *Бу хаста хәлдән котылу өчен, нинди дә булса рухи таяныч, рухи көч эзләп җәфаланды карт.* Г.Гыйльманов. *Сәлим хан кайтышлый хаста хатыны янына керде.* М.Хәбибуллин

**ХАСТАЛАНУ** *ф.* Авыру, чирләү. *Хасталанган кешенең күңеле китек, шуңа күрәме ул дингә ныграк табына, җенгә ышана, ырым-юрауларга сизгер була, күргән төшләреннән чынбарлыкны эзли ---.* К.Кәримов. *Нәкъ менә Нуриәсма хасталангач кына, бөтен авыл халкы кемнедер югалта язуына төшенә, аның бәхиллеген алып калырга өметләнә.* Р.Рахман

**Хасталана башлау** Хасталану билгеләре сизелү, күренү. *Хасталана башлау белән күрәм мин бу төш-чынбарлыкөнне...* М.Юныс

**Хасталанып бетү** Тәмам хасталану, бик нык хасталану. *Улын уйлый-уйлый хасталанып беткән ана да кызганыч ---.* М.Вәлиев

**Хасталанып йөрү** Озак вакыт дәвамында хаста хәлдә булу. *– Җитмәсә, бу араларда хасталанып та йөри әле, бичара, – диде Шәрифулла.* А.Расих

**Хасталанып киту** Тиз арада, кинәт хасталану. *Шул ятудан чын-чынлап хасталанып китте Сәләхетдинов.* Т.Галиуллин. *Мин югында ул хасталанып киткән, операция кичергән, тик миңа әйтергә кушмаган, борчылмасын, дигән...* Г.Шәйхи

**Хасталанып тору** Әле, хәзер хаста булу; күпмедер вакыт, вакытлыча хаста булу; әледән-әле хасталану. *– Хөрмәтле Бәдертдин Хәйлә капчыгы, – ди бу, – кызым хасталанып тора, терелт шуны, ялварып сорыйм!* Н.Әхмәдиев. *Әнисе хасталанып тора, шул сәбәпле шәһәр белән бистә арасында йөгереп тә уза иде бик күп гомере.* Р.Мөхәммәдиев

**ХАСТАЛЫК** *и.* 1) Чир, авыру, сырхау. *Кызларны сагыш басты: эзләгәнең табылмаса, өмет һаман саен саегая барса, ризасызлык тернәкләнә, кешеләр җирси, күңелне сагыш яулый, бәдәнне хасталык баса шул.* Р.Батулла. *Дистәгә якын табиблар, өшкерүчеләр, имчеләр дә чакырып карады, әмма аның хасталык сәбәпләрен белүче, аңлата алучы юк.* В.Имамов

2) *күч.* Нәрсәнеңдер нормадан тайпылышы; нәрсәнеңдер тискәре сыйфаты, ягы, начар гадәт. *Каян килә соң бу актив хасталык, әйтергә кирәк, харам юллар белән хакимлеккә омтылу хасталыгы?* Н.Гамбәр. *Ул шикләнү хасталыгы, курку хасталыгы белән авырган.* Р.Батулла

**ХАСТАХАНӘ** *и. фар.* Стационар дәвалау учреждениесе; больница. *Шәһәргә район үзәге аша, әни яткан хастаханә яныннан үтеп йөриләр алар.* Л.Гыймадиева. *Зур түрәләр, аларның хатыннары гына йөри торган махсус хастаханә табибларына да барып күренде.* Л.Лерон

**ХАТ** *и. гар.* 1) Нәрсә дә булса хәбәр итү, хәл-әхвәл, уй-фикер һәм хисләрне белдерү максаты белән кемгә дә булса атап, адреслап язылган текст, хәбәр; мәктүп, намә. *Тормышыма зур үзгәреш керткән бер вакыйгага булу аркасында бу хат нәкъ егерме көн өзелеп торды.* Г.Кутуй. *Эшләр болайга киткәч, мин өйгә кайтуны көтмәскә булдым, ялгышлык белән ычкындырган дорфалыгым өчен Сәрвидән кичерүен үтенеп, аны да, улым Мансурны да бик сагынуымны, еш кына төшләремдә күрүемне әйтеп җылы хат яздым.* С.Сабиров

2) Шундый язуның конвертка салып почта аша җибәрелә торган төре. *Хат китерүче малай мич буендагы кечкенә урындыкка утырды.* А.Алиш. *Габдрахман ага өстәлгә бер кочак хат чыгарып салды.* А.Хәсәнов

3) Шундый язуның конвертка салынган яки бөкләнгән, кәгазьгә төрелгән яисә башка форматларда, формаларда берәр кеше аша яки башка төрле чаралар ярдәмендә адресатка тапшырылырга тиешле төре. *Хикәядә еламыйча калган бер персонаж да юк диярлек: Галимә дә, Сәгыйд тә, хат йөртүче арадашчы да, Галимәнең ата-аналары, туганнары, хәтта Сәгыйднең каты бәгырьле булып кыланган әти-әнисе дә күз яшьләре түгәргә мәҗбүр булалар.* Р.Минһаҗева. *Бераздан Зилзилә, урыныннан торып, каяндыр бер хат алып килде һәм сүзсез генә Акболытның алдына ташлады.* Р.Гариф

4) Электрон почта яки башка каналлар, ресурслар аша җибәрелә торган электрон форматтагы хәбәр, текст. *Шушы җанисәп алдыннан Марат исемле танышым электрон почтама берөзлексез хат яудырды.* Л.Заһидуллина // Кесә телефонына килә торган кыска хәбәр, СМС. *Клара карчыкның, ковролин намазлык өстендә кесә телефонынан СМС хәбәрләр җибәреп, башка чыккан сыңар малае белән хат алышып утырган чагы булган.* К.Кәримов

5) Берәр танылган кешегә – җитәкче, язучы, җәмәгать эшлеклесенә адресланган, гадәттә, нindидер каршылыклы фикерләргә яисә адресатның аңа кадәр әйтелгән, язылган сүзләренә җавап итеп, нәрсәдер сорап яки берәр проблемага игътибарны җәлеп итү, хакыйкатьне яклау максатыннан һ.б. юлланган, матбугатта бастырылган текст; үз исеменнән яисә халык исеменнән мөрәҗәгать. *Башкортстан Президенты һәм аның улы Урал Рәхимов гамәлләрен тикшерүне сорап, Русия фиркаләренең Башкортстандагы төбәк бүлекләре һәм төрле иҗтимагый оешмалары Президент Д.Медведевка ачык хат белән мөрәҗәгать итте.* Ф.Фәтхи. *Синең аларга каршы «Ачык хат» язып бастыруың ул чагында, гомумән, талантка каршы чыгу диеп аңлашылмады микән соң?* М.Вәлиев

6) Суд эшләре, дәүләт карарлары, кануннар, акча мәсьәләләре һ.б.ш.га караган рәсми документ. *Кырымнан Үзәк Комитетка килгән рәсми хат Сталин тарафыннан көтеп алынган иде.* Р.Мөхәммәдиев // Төрле оешмаларда нәрсәдер сорау, хәбәр итү, белгертү һ.б. максаты белән языла торган хәбәр. *Сафин гаиләсенең кысынкы торак шартларында яшәүләрен исәпкә алып, чират җиткәнче, бушаган фондтан фатир бүлеп бирү мөмкинлеген карауларын сорап хат җибәрелде.* Т.Миңнуллин. *Узган ел безгә хат белән 500 дән артык кеше мөрәҗәгать итте.* Р.Миңнуллин

**ХАТА́** *и. гар.* **1.** 1) Язуда, хисаплауда ясалган ялгыш. *Мин дә әтинең хәреф хаталары белән тулы, нокта белән өтерне санга сукмаган, бары тик үзенә, яшәешенә ярдәм итү өчен алып барылган көндәлекләрен нәкъ шулай бәяли алыр идем.* Т.Галиуллин. *Әнә бит, республикада татар теленә игътибар шундый кимеде ки, кеше күз алдында еллар буе хата белән язылган килеш торса да, күрүче юк.* И.Сиражи

2) Эштә, тормышта ясаган ялгышлык, дөрес булмаган эш. *Ләлә белән танышып, дуслашып ялгышты, зур хата ясады ул.* А.Гыйләҗев. *Мин үземнең мәңге төзәтеп булмаслык хата ясавымны чирек гасырдан артык вакыт узгач, әнидән әлеге хат килеп төшкәч кенә аңладым.* В.Нуруллин

**2.** *рәв. мәгъ.* Ялгыш рәвештә, дөреслеккә туры килмәгәнчә. *Юк, уртак, сез хата сөйлисез.* Г.Әпсәләмов. *Барыбызга да мәгълүм ки, моңарчы бөтен татар милләте үз музыкасына ихтирамсыз, аның хакында хата уйлый, аның нигә җылаганын белми иде.* Г.Ибраһимов

**ХА́ТА** *и. слав.* 1) Украина, Белоруссия, Россиянең көньягындагы авылларда крестьян йорты. *Ә әтием – атаклы сәүдәгәрләр нәселенең соңгы «могикан»ы – чит-ят якта, балчык идәнле хатада яшәп, нindидер хуторда комбайнчы-тракторчы булып эшләп ни тапты да ни кырды?* Н.Саттарова

2) *сөйл.* Өй, йорт; яшәү урыны. – *Кая? – диде Зөбәер механик рәвештә. – Минем хатага, – һәм хастаханәгә чапырыш тугыз катлы йортка таба ымлады.* Д.Булатова

3) *сөйл.* Тоткыннар яши торган урын. *Хөкем карары чыкканнан соң, тоткыннар, зонага китү өчен этап көтеп, махсус хаталарда яши икән...* И.Сиражи

**ХАТА́ ИТҮ** *ф. иск. к.* **хата кылу**. *[Фатыйма:] Хата итәсез. Мин гадәти татар кызы.* Г.Исхакый

**ХАТА́ КЫЛУ** *ф.* Хаталану, ялгышу. *Хата кылып та, соңыннан гафу ителәсен белсә, кеше беркайчан да җинаять эшләүдән курыкмаячак.* Р.Батулла. *Шулай булгач, хата кылынмас дип кем әйтә алыр?* Ф.Зыятдинов

**ХАТАЛАНУ** *ф.* Хата җибәрү, хата эшләү, ялгышу. *Хаталанам – димәк, дөрес яшим, Хатамда да, димәк, казыналар.* Г.Морат. *Кайда ялгышты соң Рәхимҗан, кайчан хаталанды?* А.Әхмәтгалиева

**Хаталана башлау** Хаталанырга тотыну; хаталану билгеләре сизелү, күренү. *Хаталана башлый кыз бала, «Мин – мин икән, мин – кем икән?» дигән уй керә.* Б.Камалов. *Егетләр артык борчылмый, алар азрак хаталана башлады.* Ватаным Татарстан

**Хаталана төшү** Тагын да күбрәк хаталану. *«Хатамны төзәтәм» дия-дия тагын да хаталана төшүчеләр азмы бездә?* Мәйдан

**Хаталанып алу** Әз генә хаталану, билгеле бер вакытта гына хаталану. *Яшь чакта барыбыз да хаталанып алган инде, аңа гаҗәпләнәсе юк.* И.Нуруллин

**Хаталанып бетү** Тәмам, бөтенләй хаталану; бик күп хаталану, хаталар ясау. *Туры юлга ничек кертергә соң Хаталанып беткән заманны?!* Э.Сафина

**Хаталанып йөрү** Озак вакыт дәвамында хаталану. – *Хаталанып йөргән чакларыңны оныттыңмы әллә, әүлия булып кыланасың? – дип сүгеп атты аны апасы.* М.Вәлиев

**Хаталанып кую** Бер тапкыр хаталану. *Күрәсең, Люциягә бу нәрсә комачау булып тоелмагандыр, югыйсә ул егетне якын да җибәрмәс иде, инде башка сыймаган рәвешле хаталанып куйган булса да, безне, парлап, аның янына кунакка чакырмас иде.* М.Маликова

**Хаталанып тору** Еш, әледән-әле, гел хаталану. *Кемдер әйткән акыллы сүзгә ышанмыйча, кешеләр гел хаталанып тора.* Ф.Җамалетдинова

**ХАТАЛЫ** *с.* **1.** Хатасы, ялгышы булган; ялгыш, дөрес булмаган, хата булган. *Урамнардагы концерт-тамаша белдерүләренең, хәтта дәүләт оешмаларының ишегенә эленгән язуларның да һәрвакыт хаталы булуы йөрәкне әрнетә, телең өчен кимсенәсең.* Р.Рахман. *Дәфтәр битенә хаталы сүзләр ятты.* Д.Каюмова

**2.** *рәв. мәгъ.* Хата белән. *Военкоматтан кабер ташы да ясаттырып аласы бар бит әле тагын, анда да, таныклыктан күчереп, хаталы язарга мөмкиннәр.* Т.Әхмәдишин. *[Әни] Әтиеңнән хаталы язып көлдертмә, дигән була.* Р.Рахман

**ХАТАЛЫК** *и. ялг.* Хаталану, ялгышу очрагы, ялгыш. *Шуннан соң гына ат, хаталык белән түгел, башка бер җиргә барабыздыр, ахры, дип буйсынды.* Г.Ибраһимов. *Үземнең үткәнемдә, Ленага булган мөнәсәбәтемдә хаталык, ялгышлык бар дип, һич тә танайсым килми иде...* А.Гыйләҗев

**ХАТАЛЫ́К КЫЛУ** *ф. к.* **хаталану**. *– Я, әйтегез, – диде тамада, – мин хаталык кылдыммы?* Г.Әпсәләмов. *Мин дә синең бәндәң, ялгышлык вә хаталык кылуымнан куркып шулай иттем.* Ф.Яхин

**ХАТАСЫЗ** *с.* **1.** 1) Хатасы булмаган, дөрес. *Хәзерге әлифбабызны бер-ике генә ел өйрәнергә өлгергән, аны гамәлдә куллануdан мәхрүм ителгән булса да, аның бүген илгә язган хатлары хатасыз, хәтта күп кенә каләм ияләребезне көнләштерерлек дәрәҗәдә камил.* Т.Әйди. *Аның язулары хатасыз һәм дөрес, матур һәм пөхтә булган.* Ф.Яхин

2) Дөрес уйлый, яши торган; хаталанмый, хаталар ясамый торган. *Бу синең бәхетле чагың – Ялгышсыз, хатасыз чак.* Р.Харис

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Хата ясамыйча, дөрес итеп, тиешенчә. *– Соң сез бит бик яхшы укыйсыз, хатасыз язасыз, – ди Баттал.* Р.Батулла. *Ә мин менә нотасыз да Уйный алам хатасыз!* Р.Миңнуллин

2) Төгәл, хаталанмыйча, ялгышмыйча. *Элеккеге шинель иясенең кай төшенә пуля яки ярчык тигәнлеген хатасыз әйтергә мөмкин.* Х.Камалов. *Әти, калган бөтен кеше дә хатасыз гына яшиме?* Н.Гыйматдинова

**ХАТИМӘ** *и. гар.* 1) *иск.* Нәтиҗә, йомгак, ниһаять. *Ләкин ул гакылын җыйды да, сәгатьнең бер булганын, тиздән атасы кайтуын, дүрт-биш сәгатьтән соң каралуга китүләрен уйлап, ничек кенә булса да бу эшкә хатимә бирергә карар итте.* Г.Ибраһимов. --- *сүзенең хатимәсендә үзенең «эш эшлисе» килгәнене, бу эшсез, «идеалсыз», «чилепешле» кешеләр тирәсеннән котылырга теләгәнене, ләкин үзендә анлык куәт юк икәнлегене әллә нинди бер кыяфәт – үзүзеннән мыскыл иткән, үз-үзене әллә нинди гөнаһлар өчен җәзалаган кыяфәт белән бәян итте.* Ф.Әмирхан

2) *әд.* Соңгы сүз, эпилог. *Менә тыңла, хатимә өлешендә ни дип язып куйдым.* В.Имамов. *Әсәрнең хатимә өлеше – көндәлек рәвешендә алып барылган язмаларга нәтиҗә ясау урыны.* Г.Гайнуллина

**ХАТИРӘ** *и. гар.* 1) Баштан кичкән вакыйгалардан хәтердә калган эзләр, зиһендә саклануын дәвам иткән нәрсә; истәлек. *Салкынча келәткә кереп, хатирәләргә чумган килеш, вак-төяк эш эшләргә ярата иде Габдерәшит карт.* А.Тимергалин. *Иртәнге хатирәләр оныты лмаса да, алар күңелдә ничектер тигезләнгән һәм тоныкланган.* А.Хәлим

2) Берәр урын, кеше яки вакыйганы истә тоту, хәтерләү өчен алынган, бирелгән, ясатылган яки шул максат белән саклана торган әйбер; ядкәр. *Менә, [гөл] Зиннәтемнең хатирәсе, җан-рухы булып, бер миндә генә балкып, янып утыра, бахыркаем.* Г.Гыйльманов. *Алсу чәчкәле яран гөлләре әнисе хатирәсе булып күңелдә йөргәнгә, авылны искә төшереп, күз алдына иң башта шул яран чәчәкләре килә иде.* Г.Әдһәмова

**ХАТЛАШУ** *ф. сир.* Хат алышу, хат язышу, хатлар аркылы хәбәрләшү. *Габдулла әфәнде хакында мин Кодес-Мисыр сәяхәтләремдә бик күп ишеткән, аның берлә инде берничә мәртәбә хатлашкан булсам да, бу вакытка кадәр күрешергә насыйп булмаган иде.* Г.Исхакый. *Минем анда дусларым бик күп булды, озак еллар хатлаштык.* Кызыл таң

**Хатлаша башлау** Хатлашырга тотыну, хат язышырга тотыну. *Ничә еллардан соң туган якларына кайтып табыштылар. Хатлаша башладылар.* С.Сөләйманова. *Шуннан без хатлаша башладык.* Кызыл таң

**Хатлашып алу** Аз вакыт хатлашу. *Студент елларында хатлашып алган идек без аның белән.* Идел

**Хатлашып тору** Озак вакыт дәвамында хатлашу; даими, гел хатлашу. *Алар шулай фикер-фәтва алышып, киләчәктә хатлашып торырга сүз куешып, дусларча аерылыштылар.* С.Поварисов. *Юк, без хатлашып торабыз.* М.Кәбиров

**ХАТУН** *и. сугд.* 1) *тар.* Кахан хатыны

2) *иск.* Исем белән бергә яки аерым гына кулланылып, хатын-кызларга хөрмәтләп эндәшү сүзе. *Зөләйха бер көнне йоклап ята иде, Бер даясе кереп, аның хәлен күрде: «Әя хатун, сиңа нәрсә булды? – диде. – Ни сәбәптән мондый хәлгә төштең имди?»* Кол Гали

**ХАТ-ХӘБӘР** *җый. и.* Исәнлек-саулык, иминлек, яңалыклар һ.б. турында хат яки башка юл белән ирешкән хәбәр. *Тик бераздан аны каядыр озаттылар булса кирәк, хат-хәбәр тукталды.* М.Мәһдиев. *Нindидер ерак авылдан килгән бер хәлфәгә кияүгә чыгып, йорттан китеп барган апалары Шәмсекамәрдән дә берниндиhат-хәбәр юк иде.* Р.Рахман

**ХАТ-ХӘБӘРСЕЗ** *рәв.* Эзсез, бөтенләй хәбәрсез. *Шул китүдән, суга төшкән төсле, Хат-хәбәрсез булды Нәҗибе.* Л.Шагыйрьҗан. *Миллионнар сугыш кырында Хат-хәбәрсез югалган.* Г.Сафин

**ХАТЫЙБ** *и. гар.* 1) Оста оратор, сүзгә осталыгы булган кеше. --- *ул татар әдәбиятында буржуаның «вөҗданлы», «тәүфикъле», шашкын бер хатыйбы – ораторы иде.* Казан утлары. *Хатыйбны тыңлау*

2) Җомга көннәрендә мәчеттә мөнбәргә менеп хотбә укуга хакы булган мулла. *Мелла Габделфәттах Иске Салавычта имам һәм хатыйб иде.* Р.Зарипов

**ХАТЫН** *и. сугд.* 1) Аерым сыйфатларга, табигый үзенчәлекләргә ия булarak, ир җенесенә капма-каршы җенестәге кеше. *Бер кичтә аларның икесен ике палатага больницага салдылар: Сәләхетдин ирләр янына сыйды, Гөлбикә апаны хатыннар палатасына арба белән тәгәрәтеп алып керделәр.* А.Гыйләҗев

2) Кыз баладан һәм үсмер кыздан аермалы буларак, шул ук җенестән, ләкин олырак яки балигъ булган кеше. *Хатын, баласын җитәкләгән сыман, сакаллы кешене президиумга таба өстерәде...* А.Алиш. *Нindидер бер хатын, (рәхмәт төшкере!) яңа пешкән кайнар ипекәйне аның аркасына, түшләренә куеп җылытып, даһины үлемнән йолып кала.* А.Тимергалин

3) Гаилә корган, ир белән яшәгән ана җенестәге кеше. *Үзен күргәнем юк югын, иллә мәгәр акылсыз хатын түгелдер: безнең ялгышларда баланың гаебе юк, дигән.* А.Әхмәтгалиева. *Яшь хатын карт аучыны әтисе урынына, ә карт аучы аны кызы урынына күрде.* А.Нәҗми

4) Иргә мөнәсәбәттә: никахлы тормыш иптәше; зәүҗә. *Җан биргәндә пәйгамбәрнең янында сөекле хатыны Гайшә була.* А.Тимергалин. *Садретдин мәзин белән сүз көрәштерүдән качып, аның гаиләсенә, бигрәк тә хатыны Мәүлидә абыстайга каныктылар.* А.Хәлим

5) *к.* **ханымәфәнде**. *Ишәккә йөгән орып качыр булмас, куравычка тун кидереп хатын булмас.* Мәкаль

**ХАТЫН-КЫЗ** *җый. и.* Ирләргә капма-каршы җенестәге кешеләр; гомумән, барлык хатыннар һәм кызлар. *Ул, килеп, Асаф белән көрешкәндә, хатын-*

*кыз читкәрәк китте.* М.Мәһдиев. *Чөнки хатын-кыз, табигатьнең үзе кебек, мәңгелек сергә төренгән.* Р.Миңнуллин

**ХАТЫНЛАШУ** *ф.* Хатыннарга охшый башлау. *Ирләр хатынлашкан, хатыннар ирләшкән заманда яшибез.* Д.Сәфәров

**ХАТЫНЛЫ** *с.* Өйләнгән, хатыны булган; гаиләле. *Нәгыймәгә әйтәм: мин – бүгеннән башлап хатынлы кеше!* Г.Камал. *Бу яшьтә ир-атлар хатынлы, бала-чагалы, фатирлы һәм дачалы була.* А.Гыйләҗев

**ХАТЫНЛЫК** *и.* 1) Хатын җенесеннән булу хәле, хатын статусы. *Канунча, җинаять кылган бер кешенең хатынлыгы аны җәзадан коткарырга да, аның җәзасын киметергә дә сәбәп булырга тиеш түгел.* Г.Бубый

2) Бер ирнең хатыны булу хәле. *Ә менә Газиз бабасының күптән түгел, дөньяда бер мөслимә артыр дип, күрше чуваш авылыннан хатынлыкка бер чуваш хатынын алып килүе чынында да дөрес.* А.Хәлим. *Ә күңел өмет итә: мине Илһам хатынлыкка алыр, дип хыялланам.* Р.Батулла

3) Хатын-кызга хас табигать. *Зирәк хатын хатынлыгы белән теләсә нинди ирне дә бөгә, дигәндәй, Бакый хәзер үзе дә Гөлбикә кебек уйлый да, яши дә инде.* Р.Шәфигуллин. *Ир – ирлеген, хатын хатынлыгын итә.* Безнең гәҗит

4) *кимс.* Йомшаклык, җебегәнлек, көчсезлек һ.б.ш. сыйфатларга ишарә итеп хурлау сүзе. *Мөршидә алай да тыелмагач: – Син, әнисе, үзеңнең хатынлыгыңа барма әле! Еламагаең, гомереңбуена улап торсаң да безнеңчә булмаячак бит, – дип тиргәп тә, үпкәләп тә әйтте.* Н.Яһудин

**ХАТЫНША** *и. сөйл. кимс.* **1.** Үзен хатыннарча тотучы, хатын-кыз эшенә кысылып, хатын-кыз арасында артык күп буталып йөрүче ир кеше. *Хатынша кебек кирәкмәгән җиргә кысылып йөрмә әле...* М.Хәсәнов. *Тал төбенә качып, кызлар сүзен тыңлап йөрисең, хатынша!* Н.Кәримова

**2.** *с. мәгъ.* Үзен хатыннар кебек тотарга, хатыннар арасында булырга яратучан, хатын-кыз табигатьле. *Әле кайчан гына кыюсыз, хәтта хатынша тоелган Газиз абыйсының шулай катгый төстә, хәтта киләчәк бәхетле тормышын да яхшы күзаллап сөйләүләре Кәримәне тәмам хәйран иттеләр.* Ф.Яхин. *Әллә каян хатынша ирләр, ирдәүкә хатыннар пәйда булды.* Кызыл таң

**ХАТЫНШАК** *и. сөйл. кимс. к.* **хатынша**. *Өйләнгәнче йомыкый гына бер хатыншак иде.* Р.Батулла. *Хатыншак ир-егетләрне өнәми ул.* М.Әмирханов

**ХАТЫНШАЛАНУ** *ф.* Артык вакчылланып, хатын-кыз эшенә кысылу; үзен хатын-кыз кебек тоту. *Кулыннан эш килә торган кеше булса, хатыншаланмас иде.* М.Маликова. *Хәер, моның ише тузга язмаган фәтваларны чынга алып, барлык мөселман ирләренә дә, хатыншаланып, базар буйлап яшелчә сайлап йөрергә туры килмәгәе.* Шәһри Казан

**Хатыншалана бару** Торган саен ныграк хатыншалану; элеккегә карaганда да күбрәк хатыншалану. *Ирләр, киресенчә, картайган саен хатыншалана баралар.* М.Юныс

**Хатыншалана башлау** Хатыншалану билгеләре сизелү. *Хатыншалана башлаган бүгенге заман ир-атларын кызганам мин.* Идел

**Хатыншаланып бетү** Тәмам хатыншалану, бөтенләй хатыншалану. *Ирләр бит хәзер хатыншаланып бетте.* Безнең гәҗит

**Хатыншаланып йөрү** Озак вакыт дәвамында хатыншалану; даими хатыншалану. *Ул савымчылар арасында хатыншаланып йөрмәс.* С.Рафиков

**Хатыншаланып тору** Хатыншаланган булу; билгеле бер вакытта хатыншалану. *Бу хәл Мидхәткә ошап бетми, шулай да һәрвакыт: «Әйдә, вак-төяккә игътибар итеп, хатыншаланып тормыйм әле», – дип уздырып җибәрә.* Н.Харисова

**ХАУЗ** *и. гар. ялг. к.* **хавыз**. *Агачлык арасында чишмәдән китерелгән судан хауз ясалган.* А.Расих. *Рушанга хатынының проекты ошый иде: түбә астындагы кафе да, концерт залы да, әмма барысыннан да бигрәк ул холлны яратты – анда икенче каттан астагы кантар-кантар ташлар өстенә шарлавык ага, зәңгәрсу хауз читендә фонтан чөлтери ---.* Р.Мирхәйдәров

**ХАФА** *и. гар.* Борчу, хәсрәт, кайгы, көенеч, эч пошу, тәшвиш. *Минем хафа, минем ваем эчендә яшәүче Әдһәм Фәйзул озак еллар дәвам иткән тегүчелек эшеннән күптән түгел пенсиягә чыкты һәм моннан соң бөтен вакытын яраткан язу-сызуына бирергә мөмкинлек алды.* Т.Әйди. *Сиеры бозаулый алмый яткан крестьян төн урталарында зур хафа белән Бибинурттәнең ишеген кага, аны гозер белән чакыра иде.* М.Мәһдиев

◊ **Хафага салу** Борчу, борчуга салу. *Улының өйләнүен ишеткәч бик сөенсә дә, Мәрфуга апаны бу хат нык кына хафага салды.* Ф.Яруллин. *Аны тагын бер нәрсә хафага салды: ни сәбәпле ул Арсланов каршында торганда уттай кызышты, бит очларына, иреннәренә ялкын үрләде?* Ф.Садриев. **Хафага төшерү** *к.* **хафага салу**. **Хафага төшү** Борчыла башлау, кайгыга калу. *Чуртанны ычкындырдык бит, дип хафага төшә авыл советы активистлары.* К.Миңлебаев. *Сәкинәгә дә шулай тәэсир итте: – Я инде, газаплама, Өлфәт, – диде ул, тагын да ныграк хафага төшеп.* В.Нуруллин. **Хафа чигү** Хафалану. *Көнем бетәр, диеп хафа чикмә, фигыленә мәңге тугры син, – олуг Нәби сурга өргән чакта нота битен ачып торырсың.* З.Мансуров

**ХАФА́ БУЛУ** *ф.* Борчылу, кайгыру, хафалану. *Әмма хәлвәфрүш шулкадәр хафа булды, ачу уты йөрәген яндырды.* К.Насыйри. *– Хафа булма, колынчагым, бер җай табарбыз! – дип сүзен бетерде.* Г.Ибраһимов.

**ХАФАЛАНДЫРУ** *ф.* Хафага салу, хафалы итү. *Мөселманнарның уянуы хафаландырмый безне, ә эшләргә мәҗбүр итә.* Р.Мөхәммәдиев. *Балалары булмавы аларны бик борчыган һәм хафаландырган.* В.Ильясов

**Хафаландыра башлау** Хафаландырырга тотыну. *Ачлык шомы бу авыл кешеләрен дә хафаландыра башлады.* Н.Дәүли

**Хафаландыра төшү** Тагын да ныграк хафаландыру. *Билгесезлек авыл халкын хафаландыра төште, күпләр читкә китә башлады.* Кызыл таң

**Хафаландырып бетерү** Тәмам хафаландыру. *Синең әйтмичә китүең безне хафаландырып бетерде.* Р.Вәлиев

**Хафаландырып тору** Даими хафаландыру, гел хафаландыру

**ХАФАЛАНУ** *ф.* 1) Борчылу, кайгыру, тынычсызлану, эч пошу. *Габдерәшит бабай, күрәсең, Таймасның авыл малайлары белән дуслашып китә алмавына хафалана иде.* А.Тимергалин. *Юк, сугышка алырлар да, шунда үлеп калырмын дип, үзем өчен хафаланмадым!* В.Нуруллин

2) Мәшәкатьләнү, тынгысызлану. *Сез, өйнең хуҗасы булып, ул кадәр хафалангач, хатын-кызга ни калды?* Г.Камал. *Әсәрнең эчтәлеген кешеләрнең яна башлаган бинаны коткару чараларын күреп хафаланулары түгел,*

*бәлки, форсаттан файдаланып, бинадагы төрле әйберләрне эләктереп чыгу тамашасы тәшкил итә.* К.Гыйззәтов

**Хафалана башлау** Хафаланырга тотыну. *Сара әткәйнең үлүеннән бигрәк минем өчен хафалана башлады.* Г.Ибраһимов. *Җыелган халык Гөлҗәннәткә карап, бу хатын акылдан гына язмаса иде, дип хафалана башлады.* З.Мурсиев

**Хафалана калу** Кинәт, ни сәбәптәндер хафалану. *Хатын, иренең елавын күреп, хафалана кала: – Чү, әллә өйдә берәр хәл булдымы?* Ш.Галиев. *– Сез нәрсә?! – дип, гаепле кеше сыман хафалана калды мөдир.* Р.Мөхәммәдиев

**Хафалана төшү** Элеккегә караганда да ныграк хафалану; бераз хафалану. *Залда, сүз сорап, мохитне саклау бүлеге мөдире Азат Нигъмәтуллинның кул күтәрүен күргәч, Кадрия тагын да хафалана төште.* В.Имамов. *– Яман хәбәр әйтергә җыенмыйсыздыр бит, – диде Нияз, хафалана төшеп.* Д.Каюмова

**Хафаланып алу** Аз гына хафалану; кыска вакыт аралыгында хафалану. *Айша, ничек сүз башларга диеп, бераз хафаланып алса да, барыбер аның өчен беркем дә йомышын йомышламаганын аңгара торып, Мәрьян апага эндәште.* В.Ильясов

**Хафаланып бетү** Тәмам хафалану, бөтенләй хафалану. *Ул анда хафаланып беткәндер инде, мескенем...* М.Галәү. *Элекләрне андый чаралар хакында баш ватып, соңгы көненәчә дулкынланып, хафаланып бетә иде, ә бу юлы исе дә китмәгән.* Ф.Яхин

**Хафаланып йөрү** Озак вакыт дәвамында хафалану. *– Бар, кайт инде, хафаланып йөрмә, – дип, Ясүгәй әллә ничә тапкыр тукталган да иде, хатыны һаман-һаман иярүен белде.* В.Имамов. *Бу көннән соң Нургаян хафаланып йөрде.* З.Мурсиев

**Хафаланып китү** Кинәт хафалану. *Син ачулансаң да, бу сүзләрне яздым, гаеп итмә, бик хафаланып киттем.* К.Насыйри. *Янында ашарлык бер кисәк нәрсәсе дә булмаганга хафаланып китсә дә, үзенең куркынычлы әсирлектән котыла алуына куанып, үзен-үзе юатты.* Ф.Туйкин

**Хафаланып кую** Аз гына хафалану. *Әллә берәр җиргә китте микән, дип хафаланып куйды Нурулла.* Ф.Садриев. *Кодрәтов пистолетлының хафаланып куюын да сизми калмады, аларның пышылдашуы сагайтып җибәрде.* Р.Мирхәйдәров

**Хафаланып тору** Хафаланган хәлдә булу. *«Корыга китсә, бу чыршылар харап булмасмы?» – дип хафаланып тордың.* А.Гыйләҗев. *Инде бу адашкандыр, кайтырга юл табалмыйдыр, дип хафаланып торганда, «күккү» дип әллә каян куак астыннан атылып чыгар иде.* Ф.Яруллин

**Хафаланып яту** *сөйл.* Озак вакыт хафаланган хәлдә булу. *Син корыга хафаланып ятканнан ни файда?* А.Гыйләҗев. *– Иртүк торасың бар, ә син, карт юләр, бүтәннәр гыйшкы өчен хафаланып ятасың! – дип, үз-үзен тиргәргә тотына.* М.Зарипов

**ХАФАЛА́У** *ф.* Борчу, кайгыга салу, эчне пошыру; тынгысызлау, мәшәкатьләү. *Бу куркыныч кызның үз башын да күптән хафалый иде.* Г.Ибраһимов. *Алсу танышыбыз да, үзе дә интегеп, Гомәр атлы инженер ирен дә интектереп, һәмишә анасын хафалап, бимазалап, җиде ел гомерен исраф итте.* Ф.Дунай

**Хафалап алу** Бераз гына хафалау, аз вакыт хафалау

**Хафалап бетерү** Тәмам хафалау, бик күп хафалау. *– Аның турында әйтәсе дә юк, барыбызны да хафалап бетерде, – диде әнисе ачулы тавыш белән.* И.Нуруллин

**Хафалап йөрү** Озак вакыт дәвамында хафалау; даими хафалау. *[Фельдшер:] Бер дә юкка кеше хафалап йөриләр.* Ш.Камал

**Хафалап тору** Әледән-әле хафалау; хәзер хафалау

**ХАФАЛЫ** *с.* **1.** 1) Борчулы, кайгылы. *– Хатлары килми башлады шул, – диде Фатыйма хафалы тавыш белән.* З.Хәким. *Шундый хафалы уйлар белән эшләп йөргәндә, аны аулакта Фәймә үзе эләктереп алды.* Ф.Әмәк

2) Тынгысыз, һәрвакыт кем яки нәрсә дә булса турында кайгыртып, борчылып йөрүчән. *Зыя, син анаңа карама, ул хафалы кеше, юл ярагыңны, алачак әйберләреңне үзең барла, үзең тутыр!* Г.Ибраһимов. *Хафалы турында хафаланып йөри торгач, үзем дә хафалы кешегә әверелә́м, ахрысы.* Г.Бәширов

3) Кайгылы, мәшәкатьле, авыр, куркыныч. *Әмма кем белә, әтинең бу эше аркасында минем хафалы юллар узуым, бәлки, файдага гына киткәндер?* А.Расих

**2.** *рәв. мәгъ.* Хафаланып, борчылып, кайгыртып. *Аннары Күбәләк хафалы кычкырып җибәрде: – Күлмәгем, күлмәгем!* Р.Гариф

**ХАФАСЫЗ** *с.* **1.** Гамьсез, ваемсыз. *Илкәе шундый булгач, Хафасыз бер кеше юк.* Н.Әхмәдиев. *Анда булмәдәшләре, букет һәм бәйрәм хәсрәтләреннән ирекле хәлдә, хафасыз йокыда иделәр.* Ф.Яхин

**2.** *рәв. мәгъ.* Көенмичә, ваемсыз рәвештә; тынычланып, борчылмыйча. *Әнә шул өметсез, нурсыз хәятта да аларның тукларда, хафасыз гомер итүчеләрдә булмаган матур сыйфатлары калкып чыга: ярлылар шатлана беләләр!* М.Мәһдиев. *1707 елның көзендә кенәз Ураковның җәза отряды патша ярлыгына ышанып хафасыз яткан Алдар тарханның авылларына бәреп керә.* Р.Зәйдулла

**ХАФИ** *с. гар. иск.* Яшерелгән, яшерен. *Диделәр: «Бу хафи сернең, илаһи, хикмәтен күрсәт, Катил төсле начар эшкә ничек соң кылалар җөрьәт?»* М.Гафури. *Дүртенче гөмбәз – хафи, ягъни яшерүле.* А.Тимергалин

**ХАФИЗ** *и. гар.* 1) *иск.* Саклаучы. *Я рәхмәтле Аллаһ, я хаким, я хафиз!.. И адәм баласы, белгел, Алладан ятим калудан да бөек хафа дөньяда юктыр.* Ф.Яхин

2) Коръәнне яттан белүче; коръәнхафиз; ятлаучы, күңелдә саклаучы. *Руханилар санына шулай ук шәехләр, муллалар, имамнар, дәрвишләр, хаҗилар, хафизлар, мөдәррисләр дә кергән.* Б.Хәмидуллин

3) тар. XV–XVI гасырларда татар ханлыкларында сәркатип, хат йөртүче, хан канцеляриясендә эш башкаручы

**ХА́-ХА** *иярт.* Шаркылдап, кычкырып көлү тавышын белдерә. *Кинәт ул миңа таба борылды, әле генә төссез күзләреннән кайнар очкыннар очырып, шаркылдап көлә башлады: – Ха-ха-ха-ха-ха!* А.Хәлим. *– Каһәрле кул ул! – Ха-ха! – дип шаркылдап көлде Шакир.* Х.Ибраһим

**ХАХЫЛДА́У** *ф.* Каты кычкырып көлү; шаркылдап көлү. *Шуңа күрә ирләрнең хахылдавы Рәфиснең йөрәгенә тиде, ул Гөлфинурны кызганып куйды: – Син кайт, булмаса, – диде ул кызга сабыр гына.* А.Вергазов. *Безнең бу кадәр хахылдау һәм хихылдауга диварлар күченә, идән такталары түшәмгә күтәрелә, түшәмнеке идәннекенә алышына.* Ф.Яхин

**Хахылдап алу** Бераз, бер мәртәбә хахылдау. *– Каян килеп чыктың соң әле син? – дип хахылдап алды егет.* И.Нуруллин

**Хахылдап җибәрү** Кинәт хахылдау. *– Чәчләрең! – дип хахылдап җибәрде Җирән.* Казан утлары

**Хахылдап йөрү** Гел хахылдау, һәрвакыт, еш хахылдау

**Хахылдап куяу** Бер мәртәбә хахылдау. *Шаяртып әйткән сүземә аның да, башкалар белән бергәттән, хахылдап куйганы ишетелә.* И.Беляев. *– Пьяница, дип тә өстәмәдеме, – дип хахылдап куя кайсыдыр.* Р.Зарипов

**Хахылдап тору** Әле, сөйләү моментында хахылдау. *– Нәрсә булды, ник миңа бәйләнәсең? – диде ишек төбендә, егетләр төркеме арасында тәмәке көйрәтеп, хахылдап торучы кала кызы.* Ф.Гайнуллина

**Хахылдый башлау** Хахылдарга керешү. --- *нигәдер апасын күрүгә хахылдый башлый Алмаз.* Мәйдан

**ХАХЫЛДАШУ** *ф. урт. юн. к.* **хахылдау**. Берьюлы берничә кеше шаркылдап көлү; көлешү. *Җитмәсә, безнең учак тирәсендәгеләр авыз күтәреп хахылдаша.* М.Кәрим. *Граммофоннан немкалар хоры тиз ритмлы ниндидер көй җырлый, тамак ертып, фрицлар хахылдаша.* Җ.Дәрзаман

**Хахылдаша башлау** Хахылдашырга тотыну. *Әйттең ни, әйтмәдең ни, безне күрүгә үк хахылдаша башлыйлар.* Идел

**Хахылдашып алу** Кыска бер вакытта хахылдашу. *Махмыр төшә башлаган хатыннар, тамашадан тәм табып, хахылдашып алдылар.* Л.Закир

**Хахылдашып куяу** Бик аз гына хахылдашу. *Сакчылар хахылдашып куйдылар.* Ф.Садриев. *Аяк астындагылар хахылдашып куйдылар.* Ф.Бәйрәмова

**Хахылдашып тору** Әле, хәзер хахылдашу. *– Барыгыз әле, хахылдашып тормагыз монда, – дип куып җибәрде аларны апасы.* М.Вәлиев

**ХАЧ** *и. фар.* < *әрм.* 1) Христианлык билгесе буларак үзара турыпочмак ясап кисешкән ике таяктан гыйбарәт дини табыну әйбере; шуның символы; тәре. *Менә бөек кенәз йортындагы тәре-хач астында яна торган иң кыйбат көмеш шәмдәл-кандил алып килдем үзеңә.* Р.Батулла. *Алтын айлы ап-ак Сарайларга Кызыл хачлар элеп куйдылар. Татарларым, ыруларым минем, Нәсел горурлыгын җуйдылар.* Р.Гарифуллина

2) Кызыл Хач җәмгыяте эмблемасы: кушу билгесен хәтерләткән кызыл фигура. *Кызыл хач төшкән сумкасыннан җәһәт кенә таблетка алып, Фаягөлгә каптырды, су бирде.* Ф.Абдуллин. *Кызыл хач билгесе белән бизәлгән ак машина, олы юлда барлык утларын яктыртып, һаман шулай чыелдый-чыелдый, гаять зур тизлек белән алга чабуын дәвам итте.* Ә.Салах

**ХАЧАПУ́РИ** *и. груз.* Түгәрәкләп яки озынча түгәрәк рәвешендә җәйгән камыр өстенә күп итеп уылган сыр салып пешерелә торган ашамлык. *Зур тәлинкәгә тутырып шулпа, әнинең бәлеш сала торган табасы хәтле тәлинкәдә салат, аннан да зуррагында – итле ризык һәм ахырдан дүртебезгә дүрт хачапури!* Сөембикә

**ХАЧЛЫ** *с.* 1) Хач тамгасы булган; тәреле. *Тышта калган күзем ярты караңгылыкка өйрәнеп өлгергәч, мин үземне хачлы бер өйдә икәнемне аңладым.* Г.Исхакый. *Алай гына да түгел, башка диндәге кыз белән танышып, муенына ул бүләк иткән хачлы чылбырны да тагып куйды.* Шәһри Казан

2) Кызыл Хач җәмгыятенең эмблемасы төшерелгән. *Теге кызыл хачлы машина белән ташыйлар.* З.Зәйнуллин. *Кызыл хачлы махсус машиналар да җиңел генә узган.* Т.Нәҗмиев

**ХАЧЛЫ́ ЙӨРЕШ** *и. к.* **тәреле йөреш**. *Хачлы йөрештә йөзгә якын кеше катнашты*

**ХА́Ч МАНУ** I *и. дини* Чумылдыручы Иоан (Яхъя) пәйгамбәрнең Христосны Иордан (Үрдүн) елгасында чумылдыруына багышланган православие диненең унике олы бәйрәмнәреннән берсе. *Алдагы көннәрдә суыта барып, 19 гыйнварда – православие вәкилләренең изгеләштерелгән бәкегә чуму традициясе башкарыла торган Хач ману бәйрәмендә исә көндез – 15–20, төнлә 20–25 градуска кадәр салкын була, дип хәбәр итә ТР Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне күзәтү идарәсе.* Шәһри Казан. *Православие динен тотучылар шуны исләрендә тотсыннар иде: Хач ману бәйрәмендә аруландырылган бәкедә яки башка сулыкларда коену – ул кешенең гөнаһларын юуы дигәнне аңлатмый ---.* Авыл таңнары

**ХА́Ч МАНУ** II *ф. дини* Христианнарда, суны аруландыру максаты белән, махсус ясалган бәкегә алтарь хачын батырып алудан гыйбарәт йоланы үтәү. *Һәм моны бөтен авыл дерт итеп сөйли иде: – Бүген Чүриле урыслары хач маналар...* М.Мәһдиев. *Ә инде Яңа елда «хач манган» суда христианнар кебек бәкедә коену мөселман кешесен исламнан чыгарып җибәрә, бу бәхәссез шулай.* Р.Хәбибулла

**ХАШИЯ** *и. гар.* 1) Китап бите, кулъязма һ.б.ш.ның читендә текстсыз калдырыла торган тар чиста буй. *Шунлыктан әдәби текстларга авторыннан гайреләрнең төзәтмәләр кертүе бары тик аңлатма-искәрмәләр характерында юл читендә, хашияләрдә генә мөмкин булган.* Ф.Яхин

2) Китап, кулъязма һ.б.ш.ның читендәге аңлатма язуы, комментарий, ачыклама. *Вахидның үзенең китапларын, читләренә хашияләр язган китапларын да калдырырга, бабадан атага, атадан балага калып килгән китапларны да калдырырга шәкерт угылы юк...* Г.Исхакый. *Шулай итеп, элек мәдрәсә шәкертләре гарәпчә язылган һәр текстны су кебек эчеп тә, шуңа шәреххашия (коментарий) баглау белән шөгыльләнгән кебек, монда да урысча сүзнең төбе-тамыры ни икәнен дә уйлап тормастан, шуңа бездән иллюстрация эзләүдән ясалган ялгыш килеп чыкканын күрәбез.* Н.Исәнбәт

3) Бер китапның эчтәлеген ачыклаган икенче бер китап, әсәр. *Китапка «Төхфәтел-мөлек» хашиясе өстәлгән булып, анда төш күрүгә һәм төш юрауга кагылышлы комментарийлар урнаштырылган.* А.Тимергалин

**ХӘБӘР** *и. гар.* 1) Берәр нәрсә турында белгертү, булган вакыйгалар, яңалыклар белән таныштыру өчен әйтелгән, сөйләнгән яки язылган сүз; мәгълүмат, белешмә. *Хәбәр артыннан хәбәр – берсе икенчесеннән куркынычрак.* М.Мәһдиев. *Бер атнадан янә, солтан килә, дигән хәбәр таралды.* В.Имамов

2) Вакытлы матбугатта басылган мәкалә, корреспонденция. *Интервью басылып чыкты, шуннан соң ул мине чит итмәде, очраганда эш, тормыш, газетабыздагы хәбәрләр турында сөйләшә торган булып китте.* А.Гыйләҗев. *Бу заманда газета-журналлардагы хәбәрләргә ышанып та булмый, кайберләренә ышанасы да килми.* М.Хуҗин

3) Яңалык. *– Әнкәй, мин китәм! – диде кычкырып, ниндидер сөенечле хәбәр алып кайткан шикелле.* Н.Фәттах. *Йосыпова, мин сезгә сөенечле хәбәр алып килдем.* А.Әхмәтгалиева // Төрле имеш-мимеш, дөреслеге төгәл билгеле булмаган сүз, гайбәт. *Көн дә бер яңа хәбәр авылны болгата.* А.Алиш

4) *сөйл.* Кемнең дә булса хәле, исәнлеге, берәр кая барып җитү-җитмәве

һ.б. турында мәгълүмат, белешмә, хат. *Җиттем, әнкәй, рәхмәт, хәбәреңне алдым.* А.Гыйләҗев. *Аликтан бер хәбәр булмаганга аптырап, Йолдыз әллә ничә тапкыр аңа шалтыратып карады ---.* Р.Габделхакова

5) Кесә телефоны аша, Интернет аркылы җибәрелә торган кыска мәгълүмат, СМС, аудио-видео язмалар һ.б.ш. *Русланга хәбәр язып җибәрдем дә, чыкса чыгар, чыкмаса юк дип, кесә телефонын сүндереп үк куйдым.* А.Әхмәтгалиева

6) *лингв.* Җөмләнең ия турында хәбәр итә һәм аңа буйсына торган икенче баш кисәге. *Җөмләнең хәбәре үз урынын алмаштырып килә: «Көтсәң дә, кайталмавымны Ит гафу син, ит гафу».* А.Йосыпов. *Баш җөмләнең хәбәре хәзерге һәм киләчәк заманнарда, я боерык фигыль формасында була.* Ф.Галләмов

◊ **Хәбәре булмау** Нәрсәнедер бөтенләй белмәү, аңламау, нәрсә beləндер таныш булмау. *Мине надан бер кибетче дип уйлыйсыз инде, дөнья хәлләреннән хәбәре юк дип беләсез?!* А.Гыйләҗев. *Ә анда, иске ояда, еллар буе күзен аңа төбәп яшәгән хатын нишли, ниләр кайный аның эчендә – анысында егетнең хәбәре юк, әйтерсең ул кеше белән бөтенләй танышлыгы да булмаган.* М.Маликова. **Хәбәренә дә алмау** Бөтенләй игътибар итмәү. *Секретарь, аның карашын хәбәренә дә алмагандай, горур кыяфәт белән шык-шык басып чыгып китте.* М.Маликова. **Хәбәрендә (дә) юк** Уйлап та бирми, исе дә китми. *Ә бу малайның хәбәрендә дә юк, йоклап ята.* Г.Камал. *Тычкан тауга үпкәләгән, ә тауның хәбәрендә дә юк, диләр.* Т.Галиуллин. **Хәбәр өзелү** Мәгълүмат булмау; бернинди дә хәбәре, хаты килмәү. *Алдагы көннәрдә дә Фәйзерахманнан хәбәр өзелеп торулар байтак булды.* Б.Камалов. *Соңра, Таҗикстанда чуалышлар башлану белән, хәбәре өзелгән, исәнмеюкмы – билгесез икән.* И.Сабиров

**ХӘБӘРДАР** *с. гар.-фар.* **1.** Берәр эш яки вакыйга турында белә торган, ишеткән, белгән; мәгълүматы булган. *Аның бәхетенә, мыеклы агай шактый белдекле, хәбәрдар кеше булып чыкты.* М.Хәсәнов. *Һәм бар нәрсәдән дә хәбәрдар вәзир Камай кенәздән бер дә юкка гына курыкмый иде, әлбәттә.* М.Хәбибуллин

**2.** *хәб. функ.* Таныш; нәрсәне дә булса белү, хәбәре булу. *Дөнья хәлләре белән өстән генә булса да хәбәрдармы?* А.Хәсәнов. *Ул Баян батырның сәфәре турында да хәбәрдар булып чыкты, ике кулын сузып, үзе каршы килде.* В.Имамов

**ХӘБӘРДАРЛЫК** *и.* 1) Белемлелек, компетентлылык; күп мәгълүматлы, күп нәрсәдән хәбәрдар булу сыйфаты. *Аны эшкәртү өчен генә дә, бер-ике ел гыйльми эзләнү һәм, иң мөһиме, күпкырлы хәбәрдарлыкка ия булу зарур.* А.Тимергалин. *Газинур Морат китапларын, үзен күреп белмәгән укучы укыса да, аның һәм фольклордан, һәм классик әдәбияттан, һәм заман эксперементлары белән мавыккан яшьләр иҗатыннан хәбәрдарлыгын тотып алачак.* Р.Рахман

2) Иҗтимагый тормыштагы барлык вакыйгалар, яңалыклар турында халыкка, җәмәгатьчелеккә билгеле булу һәм бу хакта ачыктан-ачык, ирекле фикер алышу, сөйләшү мөмкинлеге; мәгълүмат иреге, ачыклык. *Булсын безгә хәбәрдарлык, ирек, Безне беркем тыеп тормасын!* Г.Афзал. *Хәбәрдарлыкның, демократик җәмгыятькә таба йөз тотуыбызның бер бизәге түгелмени бу?* Р.Фәйзуллин

**ХӘБӘ́Р ИТҮ** *ф.* Сөйләп, язып я башка юл белән белгертү, сөйләп бирү. *Ул кояш чыгуны тереклек дөньясына хәбәр итә.* М.Мәһдиев. *Без Мәскәүдә урнашуга хәбәр итәрбез.* Р.Галиуллин

**ХӘБӘРЛӘШҮ** *ф.* 1) Хәбәр алышу, хат язышып яисә телефон, Интернет аша хәл белешү, аралашу. *Моны ул телефон аша да белешә алыр иде, тик чыбык аша хәбәрләшү бер хәл, ә кеше үзе килеп итагатьле генә үтенсә – монысы инде бөтенләй икенче эш.* З.Мурсиев. *Ул минем Ленинградта яшәүче апалар, әтинең сеңелләре белән элемтәдә, хәбәрләшеп, хатлар алышып тора.* Т.Галиуллин

2) Сөйләшү, яңалыклар белән уртаклашу. *Күрешеп, аралашып, хәбәрләшеп тордык.* Р.Миңнуллин. *Нишләсәк тә, бер-беребез белән хәбәрләшеп, киңәшеп эшлик.* Ф.Сафин

**Хәбәрләшә башлау** Хәбәрләшергә тотыну. *Без хат аша гына хәбәрләшә башладык.* Х.Камалов. *Аның белән Мәскәүнең иң зур генераллары хәбәрләшә башлады, киңәшләрен биреп, төзәткәләп тордылар.* Ф.Бәйрәмова

**Хәбәрләшеп алу** Аз гына хәбәрләшү. – *Тәк, эшнең болай торуы гаҗәп бит әле аның, – дип куңелсезләнде прокурорыбыз, соңгы хәлләр турында берике сүз хәбәрләшеп алгач.* Н.Акмал. *Изге урынга килеп кергән шикелле, һичкем кычкырып сөйләшергә базнат итми, ым кагып кына исәнләшәләр, ярты тавышка гына, бер-ике сүз белән генә хәбәрләшеп алалар, тегe яки бу портрет турында фикер әйтешәләр.* З.Мурсиев

**Хәбәрләшеп килү** Билгеле бер вакыттан бирле хәбәрләшү. *Без аның белән ике елдан артык хәбәрләшеп килдек тә, аннары аралар өзелде.* Р.Вәлиева

**Хәбәрләшеп тору** Озак вакыт дәвамында хәбәрләшү, әле хәбәрләшү, даими хәбәрләшү. *Хәбәрләшеп торырбыз, дип аерылышкан булсак та, ни өчендер Сарьяннан хат-хәбәр күренмәде.* М.Шабаев. *Ә татар авыллары үзара һәрчак хәбәрләшеп торган, өстәвенә алар арасында сәүдәгәрләр юлы өзелмәгән.* В.Имамов

**ХӘБӘРСЕЗ** *рәв.* **1.** 1) Үзе турында белдермичә, хәбәр җибәрмичә, хат язмыйча. *Бервакыт таң алдыннан бай бернинди хәбәрсез Мәкәрҗә ярминкәсеннән кайтып төште.* М.Галәү. *Алты ел хәбәрсез югалып тордың.* Р.Мулланурова

2) Бернәрсә дә уйламыйча, белмичә, кайгысыз. *Җүнле карт булса, шушы көнгә хәтле хәбәрсез яшәр идеме ул?* Р.Сәгъди. *Алар йорт хуҗасының шикле эшен фаш итәргә йөриләр, кызчык бер хәбәрсез йоклап ята торгандыр.* Ф.Сафин // Кемнән дә булса хәбәр алмыйча. *Яудан соң бераз тынычланды бугай, хәбәрсез яшәп ята, ул-бу ишетелми, хәтта аны яу хәрәкәте дә борчымый бугай.* М.Хәбибуллин. *Ул беркавым хәбәрсез торды бит.* Р.Кәрами

**2.** *с. мәгъ.* 1) Нәрсәне дә булса белми торган, белмәгән. *Мәктәптә алман телен җирән немец өйрәтә башлагач, аның бу якларга ничек килеп эләгүе, кем булуы турында хәбәрсез укучы балалар фашизмга нәфрәтләрен җирән Конрадка күчерәләр.* Т.Галиуллин. *Белгечләрдән әлеге технологияне кат-кат сөйләтсәк тә, геология һәм минералогия өлкәсеннән хәбәрсез кеше буларак, шунысын гына аңладым: вагонеткаларга төялгән руда шахтадан казылмаларны баету фабрикасына килеп эләгә.* Сөембикә

2) Мәгълүматсыз, белемсез. *Ул шул яшькә җитеп, хатын-кыздан һич берәү белән мөнәсәбәттә булганы юк, бу бабта үзен бөтенләй чит, хәбәрсез саный иде, шуңар күрә Җиһангирларның сүзенә катышмады.* Г.Ибраһимов. *Безнең укучы исә халык шигыренә күнеккән, ул классик шигырь хасиятеннән хәбәрсез, аның колагына безнең иске шигырь ритмны бозу булып тоела.* Н.Хисамов

**ХӘБӘРСЕЗЛЕК** *и.* Хәбәр, мәгълүмат булмау. *Монда очрашу шатлыгы да, югалту кайгысы да, хәбәрсезлек фаҗигасы да – бар да бар ---.* Р.Батулла. *Ләкин ничәмә еллар хәбәрсезлектән күңелендә нәрсәдер сынган иде Харис абыйның.* Н.Кәримова

**ХӘБӘ́Р-ХӘТЕР** *җый. и.* Язмача яки телдән алынган мәгълүмат, берәр төрле хәбәр. *Сүзем шул: Наилдән, башкалардан хәбәр-хәтер булса, ирештерергә тырыш.* А.Гыйләҗев. *Ләкин ул ни сәбәптәндер авылыннан күченеп китәргә мәҗбүр булган һәм шул китүеннән бер тапкыр да кайтып күренмәгән, хәбәр-хәтере дә ишетелмәгән.* М.Кәбиров

**ХӘБӘРЧЕ** *и.* 1) Хәбәр бирүче, хәбәр китерүче, яңалык әйтүче, хәбәр җиткереп торучы. *Җимшәннәр Мәргән белән 4–5 егетләрен җибәрделәр: алар ике арада хәбәрче булырга тиешләр иде.* И.Хуҗин. *Әнә шунда ишектә сенат хәбәрчесе пәйда була.* М.Хәбибуллин

2) Армиядә һәртөрле хәбәр, мәгълүмат йөртүче. *Хөкем башланганнан бирле --- гаскәри хәбәрчеләрнең авылларга, заводларга, казармаларга чәчелгән зурлыкечкенәле оешмаларыннан туктаусыз кәгазьләр, карарлар ява.* Г.Ибраһимов

3) Вакытлы матбугатка, радио, телевидениегә һ.б.ш. хәбәр, мәгълүмат әзерләүче, җибәреп торучы хезмәткәр, корреспондент. *Муса Җәлилне «Кызыл Татарстан»ның махсус хәбәрчесе итеп фронтка җибәрү турында Фадеевның Главпур белән сөйләшүен дә көтмичә, шагыйрь, үзе теләп, фронтка китеп барган иде.* Г.Әпсәләмов. *Элегрәк, мин гәзиттә эшли генә башлаганда, актив хәбәрчеләрне өч ай саен редакциягә, тыйнак кына чәй табынына җыя торганнар иде.* З.Мифтахов

4) *күч. шигъ.* Булачак вакыйга, хәл һ.б. турында алдан белдерә, сиздереп тора торган билге, ым, күренеш. *Ә менә безнең көннәрдә шундыйрак хәлләр шул: яз хәбәрчеләре – көтеп алган кунакларыбыз – туган якларына елдан-ел азрак әйләнеп кайта.* А.Хәсәнов. *Барабан тавышы һәм учак – шул зәхмәт туенның иң беренче һәм иң шомлы хәбәрчеләре иде.* Г.Гыйльманов

**ХӘБӘРЧЕЛЕК** *и.* Хәбәрче (*3 мәгъ.*) хезмәте, эшчәнлеге. *Тагын бераздан исә Мәскәүдә «Азатлык»ның хәбәрчелек бюросы ачылды.* Т.Әйди. *Күптән түгел хәбәрчелек эше буенча шушы авылда булырга туры килде.* Г.Галимуллина

**ХӘБӘШ** *и. гар. тар.* 1) Эфиопиядә яшәүче халык һәм шуның бер кешесе. *Әл-Әзһәр университетының ректоры Мәхмүт Шәлтут, шуларга өстәп, Коръән битләрендә байтак кына хәбәш, төрек, ассирин сүзләре бар икәнен исбат итә.* Г.Гобәй. *Пушкин – чыгышы белән хәбәш (эфиоп).* Х.Миңнегулов

2) *иск.* Кара тәнле кеше, негр

**ХӘБӘШИ** *и. гар. тар. к.* **хәбәш**. *Менә шушы сәбәптән, хәбәшиләр төрле сүз йөртә башладылар: падишаһ итеп аның абыйсын куярга кирәк, юкса бу олугыбызның бер генә малае бар.* Ф.Яхин

**ХӘБЕС** *и. гар. иск.* Бик, ябып тотылу, тоткынлык. *Бик зур бәла чыккан анда: дустымның атасы белән энесен хәбескә ябып куйганнар.* Т.Әйди. *Гарәпләр арасында барган шушы башбаштаклыкны ислам халкы бик авыр кичерде, шушы рәвешле ике ел диярлек хәбестә (тоткынлыкта) яшәгән төсле тордылар.* Ф.Яхин

**ХӘБЕ́С ИТҮ** *ф.* Кулга алу, тоткын итү. *Аннан Рум падишаһы аны хәбес итте.* Ф.Яхин // Бикләп тоту, ябып кую, иректән мәхрүм итү. *Болар хатыннарының гыйффәтләренә ышанмайлар, аларны хәбес итәләр вә өстләреннән бер сакчы куялар.* Г.Бубый. *Бу көннең гүзәл бер гадәте бар: тотылган, хәбес ителгән кошлар, залим кошчыларының читлекләреннән алынып, сөеклеләренә кавышырга очарлар.* Э.Нигъмәтуллин

**ХӘБЕ́С КЫЛУ** *ф. к.* **хәбес итү**. *– Хәбес кылынуың хакында хәбәрне алгач та нык гарьләнгән идем, ә шушындый да аяусыз мәсхәрәгә дучар булуыңны күргәч, мин аң-зиһенсез калдым, – дип ачына-ачына сөйләнеп килүче дустын да күрмәде ул.* В.Имамов. *Төп максат – мөдәррисләрне хәбес кылу, --- мәдрәсәне ябу түгел.* Р.Зарипов

**ХӘБЕСХАНӘ** *и. гар. иск.* Төрмә, зиндан, тоткыннар йорты. *Фәхешханә – болгар кызларыннан, хәбесханәләр болгар егетләреннән бушана бара иде.* Г.Исхакый. *Пычрак урамнардан бер казак белән полиция юлдашлыгында шәһәр хәбесханәсенә озатылачакбыз.* Э.Нигъмәтуллин

**ХӘВАРИ** *и. гар. иск.* Ярдәмче, булышучы; Гайсә пәйгамбәрнең унике апостолының һәрберсе. *Анда хәзрәте Гайсәнең шәкертләре, ягъни хәвариләр булганнар.* Ислам – татарлар һәм мөселманнар

**ХӘВЕФ** *и. гар.* 1) Курку, шик, шөбһә, шом, борчу. *Картның ябык йөзендә нииндидер зур бәла барлыгын белгерткән хәвеф ярылып ята иде.* А.Вергазов. *Солтанъярның күңелен бераз хәвеф борчыса да, каршы килә алмады.* З.Мурсиев

2) Бәла, бәла-каза, бәхетсезлек. *Кунакларны сыйлау белән мәш килгән Фәнисә хәвеф якынлашканын сизмәде дә.* Г.Бәйрәмова. *Яшь чагында без синең белән мәчет юлын таптамасак та, укыган догаларыбыз гап-гади такмазадан узмаса да, инде сугыш ачылып илдә хәвеф башлангач, Аллаһы Тәгаләне ешрак искә төшердем шул мин, кем, Сөләйман яшьти.* Д.Салихов

◊ **Хәвеф астына кую** Куркыныч астына кую. *Шулай итеп, Аллаһка буйсынырга яраклы итеп барлыкка китерелгән бөтен әгъзаларын, организмын да хәвеф астына куя, харап итә.* Ф.Бәйрәмова. *Үз тормышларын зур хәвеф астына куеп, бу шәхес турында тик ишетеп, кайсыберләре, бәлки, күреп кенә белгән бөтенләй башка авыл кешеләре эшләгән бу изгелекне.* Р.Зарипов. **Хәвеф астында** Куркыныч астында. *Сугыш башлангач, изүче белән изелүче, кулларына корал тотып, немец яуларына каршы китте, әмма, алар икесе дә гел бер уйда, гел бер теләктә, бер үк хәвеф астында иде, дип расларга мөмкинме соң?* Т.Әйди. *Автор үлем картиналарын биргәндә үзенә карата рәхимсез, ул конфетланмый, сугышта солдат та, командир да бер үк хәвеф астында икәнен күрсәтә.* М.Мәһдиев. **Хәвефкә салу** 1) Куркуга, борчуга, шөбһәгә төшерү. *Билгеле, ишан хәзрәтләренең игъланын алар да ишетәләр, һәм, билгеле инде, бу хәбәр аларны шактый хәвефкә сала.* Ә.Еники. *Шул ук вакытта аның күпләрне аптырашта калдырган, хәвефкә салган сәер яклары да бар иде.* Т.Галиуллин; 2) Бәхетсезлек, уңышсызлык китерү. *Әмма, «без өйләнгәч, төн кыскарды» дигәндәй, инде хөкүмәт бюджет проекты эшләргә өйрәнеп беткәч кенә, бөтен Җир шарын хәвефкә салып, икътисад гарасаты – дөньякүләм кризис пәйда булды, һәм ул безнең илне дә читләтеп үтмәде.* Р.Вәлиев

**ХӘВЕФЛӘНҮ** *ф.* Курку, бик нык борчылу, кайгыру, шикләнү. *Ә менә күңелне бернишләтеп булмый, хәвефләнә.* В.Нуруллин. *Хәер, җәлләүдән дә бигрәк, малайның киләчәген уйлап хәвефләнү аны тимер кыскычтай кыса.* Р.Мулланурова

**Хәвефләнә башлау** Хәвефләнергә тотыну. *Утын кимегәнне күреп хәвефләнә*

*башлаган карчыкны юатыр өчен, үткән якшәмбедә, ял көнне, Миңнурый белән Мәүлия, үрәчәле чәнәшкәгә җигелеп урманга барып, түбәләмә итеп өеп каен ботаклары алып кайттылар.* Я.Зәнкиев. *Инде газиз җаным өчен хәвефләнә башладым: «Мә, алыгыз!» – дидем дә мин, граната ташладым.* Р.Тимершин

**Хәвефләнеп алу** Кыска вакыт арасында хәвефләнү, аз гына хәвефләнү

**Хәвефләнеп бетү** Тәмам хәвефләнү, бик нык хәвефләнү. *Абыйсы әйткән сүзләрне уйлап хәвефләнеп бетте Әнисә.* Туган як

**Хәвефләнеп йөрү** Озак вакыт дәвамында хәвефләнү; әле, хәзер хәвефләнү. *Ә бит Фәләх, «кызый»ны да болай гына калдырмаганнардыр, аны ире я бик шәпләп яргандыр яки бөтенләй аерылышканнардыр ук дип, хәвефләнеп йөргән иде.* В.Нуруллин

**Хәвефләнеп кую** Бераз яки сирәк кенә хәвефләнү. *Улының борчулы йөзен күреп, ана үзе дә хәвефләнеп куйды.* Р.Ишморатова

**Хәвефләнеп тору** Хәвефләнгән хәлдә булу. *Шулай ни уйларга белмичә хәвефләнеп торган чакта, ниһаять, егетебездән хат килеп төште.* Ә.Еники. *Салкын тимәгәе дип хәвефләнеп торырга аның вакыты юк.* Ф.Хөсни

**ХӘВЕФЛЕ** *с.* 1) Куркыныч, борчулы, шөбһәле; күңелгә курку, борчу, шом сала торган. *Аннан тыш, клуб башына эленгән кара тәлинкәдән хәвефле хәбәрләр ишетелеп кенә тора.* З.Зәйнуллин. *Эш ничек кенә авыр, хәвефле булмасын, Нияз өчен зур куаныч бар.* Д.Каюмова

2) Хәтәр, бәла-каза, бәхетсезлек китерә торган. *Ләкин, кемнәрнең организмында тыныч рәхәтлектән бизеп хәвефле көрәшкә ташлану дәрте көчлерәк булган, ахыр чиктә дөнья йөзендә шуларның нәселе калган.* З.Мифтахов. *Шушы сукыр ышану булмаса, кем үз улын хәвефле юлга озатыр иде икән соң?* З.Мурсиев

**ХӘВЕФСЕ́З-ХӘТӘРСЕЗ** *рәв. к.* **хәвеф-хәтәрсез**. *Ләкин тәҗрибәле очучылар, хәвефсез-хәтәрсез генә очып, тагын бер сәгать үтте дигәндә, Урта диңгез өстенә килеп чыктылар.* И.Хуҗин. *Кибән яныннан хәвефсез-хәтәрсез генә кузгалып киткән идек.* В.Нуруллин

**ХӘВЕ́Ф-ХӘТӘР** *җый. и.* Төрле бәла-каза, хәвеф. *Урманга булыр файдаң: ут-күздән, хәвеф-хәтәрдән, бәла-казадан, урман каракларыннан сакларсың.* К.Җәмит. *Ул аларга теге көндәге хәвеф-хәтәрне гел исләренә төшереп торды.* Д.Каюмова

**ХӘВЕ́Ф-ХӘТӘРЛЕ** *с.* Куркыныч, бәла-казалы; бәхетсезлек, бәла-каза булып торган. *Әмма хәлләр хәвеф-хәтәрле була бара иде.* Х.Камалов. *Шундый өметле уйлар күңел түрен җылытып-нурландырып торганга күрә генә, хәвеф-хәтәрле озын юлны адашмый, куркудан саташмыйча уза алгандыр, бәлки.* Р.Мулланурова

**ХӘВЕ́Ф-ХӘТӘРСЕЗ** *рәв.* Бәла-казасыз, бәла-казага калмыйча, юлыкмыйча; хәвефсез. *Төшеңә килгәндә, минемчә, сыерыгыз шушы көннәрдә хәвеф-хәтәрсез генә бозаулар, боерган булса.* Г.Галиева. *Соңлап килгән яңгыр төн куна инде ул, хәвеф-хәтәрсез генә үтеп китсен.* Г.Гомәр

**ХӘД** *и. гар.* 1) *иск. к.* **хәт**

2) *дини* Ислам шәригатендә эчкечелек, ялган шаһитлык, яла ягу кебек җинаятьләр өчен казый тарафыннан билгеләнә, камчы яки таяк суктырып үтәлә торган җәза төре

**ХӘДИС** *и. гар. дини* 1) Мөхәммәд пәйгамбәрнең төрле сүзләрен һәм гамәлләрен яки аның нинди дә булса вакыйгага мөнәсәбәтен белдергән хәбәр. *Рәсүлебез үзенең бер хәдисендә дә: «Дин – ул җиңеллек», – дип әйткән бит.* Р.Вәлиев. *Дөнья малы кызыктырса, Пәйгамбәрнең шушы хәдисләрен күздән кичерәсең.* Н.Гыйматдинова

2) Шуларны өйрәнә торган фән. *Хәдистән имтихан бирү*

**ХӘЕ́Р** *и. гар.* **1.** 1) Яхшылык, изгелек, игелек, файда. *«Шәфкатьле бул, улым», – дип, бала күңеленә изгелек орлыклары салу – хәернең тагын да зуррагы икән.* Н.Гариф

2) *сөйл.* Садака. *– Башкорт йортына килеп, мәчеткә садака бирүегезгә бик тә рәхмәт, – дип догалар укып, хәернең бирелү суммасын бер биткә теркәп куйды.* Ф.Сафин. *Бу тирәдә шушылай итеп йөрүче бердәнбер татар әбие булгач, бөтен татар хәерне аңа бирергә тырыша.* М.Кәбиров

**2.** *хәб. функ.* Яхшы, ярыйсы, хәерле. *Илдарханны үзебез исән чакта башлыкүзле итү хәер иде лә.* М.Хуҗин. *Аның белән ике арадагы тезгенне уяу тоту хәер.* В.Имамов

◊ **Хәере белән** Алда буласы эшхәлне көткәндә, аның уңышлы, файдалы булуын теләүне белдерә. *Дөньялар тынычлануга, хәере белән исән-сау әйләнеп кайтуга булсын инде.* Г.Бәширов. *Хәере белән йөреп кайтсын синең тәвәккәл картың.* А.Гыйләҗев. **Хәерен күр(ергә булсын)** Нинди дә булса яңа әйбер турында, «файдасын күрергә булсын», «яхшы булсын» дигән мәгънәдә әйтелә торган теләк. *Спорт мәйданчыгы шушы җирлектә яшәүчеләр өчен төзелгән бит ул, хәерен күрергә булсын.* Туган як. **Хәер эстәү** Садака, акча сорау, теләнү. *Юлыгу дигәнебез әлеге шул хәер эстәгәндә булды инде.* В.Нуруллин. *Алар йортыкаралтысы янып беткәч хәер эстәп чыккан сукбайга тиң.* В.Имамов

**ХӘ́ЕР** *кер. сүз.* Сөйләм барышында фикернең кинәт кенә үзгәрүен, капмакаршылык булуын, икеләнеп, кыюсызланып калуны яисә фикергә күпмедер каршы килә торган өстәмә ачыклык кертүне белдерә. *Хәер, безнең өйгә көнбагыш мае бөтенләй дә керми – исен яратмыйлар.* Б.Рәхимова. *Хәер, ул аңлый: болар барысы да – юклыктан, ачлыктан бит.* А.Хәлим

**ХӘЕРДОГА** *и. гар.* Изге теләк, яхшы дога; яхшы теләктә булу. *Искә алыгыз, мин мәңгегә сезгә Яшәрмен гел хәердогада.* В.Галиев. *Маһинур әби кече улы Габделбәр, килене Саниянең кадер-хөрмәтендә балаларының чын Кеше булуы белән горурланып, аларга хәердога кылып яши.* Т.Нәҗмиев

**ХӘЕРЛЕ** *с.* **1.** Яхшы, файдалы; уңышлы. *Вә Хак Тәгалә һәр эшеңне хәерле итә, сиңа яхшылык бирә, морадыңа ирешерсең, иншалла.* Г.Бәйрәмова. *Һөҗүмнең ахыры хәерле бетмәде.* А.Нәҗми

**2.** *хәб. функ.* Яхшы, кулай; кирәк, тиеш. *– Тик тор, унҗиде яшьлекне бирмисең, бу эшне тиз тоту хәерле, – дип кырт кисә карт.* Г.Гомәр. *Аның өчен кеше күзеннән ерактарак булу хәерле.* В.Нуруллин

◊ **Хәерле(гә) булсын** Берәр эш-хәлне яхшыга юраганда, нәрсәнең дә булса яхшы, матур, тыныч үтүен теләгәндә әйтелә. *– Ярар, алды-арты хәерле булсын, сандыгыңны әтиең кичкә китерер, – дип, ничек тиз керсә, шулай тиз чыгып та китте.* М.Мәһдиев. *Ходайның рәхмәте, яр буенда алардан башка берәү дә юк икән бит, хәерлегә булсын.* В.Имамов. **Хәерлегә түгел** Ахыры яхшы бетмәс дип уйлап, борчылып, кисәтеп, шикләнеп әйтү. *Җирдән ераклаша, читләшә бару хәерлегә түгел ул, улым.* А.Вергазов. *Мондый җилкенүләрнең ахыры, гадәттә, хәерлегә түгел.* З.Хөснияр. **Хәерле иртә** Иртән-

ге якта сәлам бирү, сәламләү сүзе буларак кулланыла. *Хәерле иртә, йокылар тәмле булдымы йомшак түшәктә?* Г.Каюмов. **Хәерле каза булсын** Нинди дә булса бәла-каза, күңелсез хәл, югалтудан соң, «башка булмасын», «ахыры шул булсын» мәгънәсендә әйтелә торган теләк. *Ул моның өчен бик кайгырмады, хәерле каза булсын, диде дә, сыерын сатып, тагын ат алды.* Г.Толымбай. *Ләкин карт моңа әллә ни кайгырмый, бу өч үлемне бергә бәйләүче Ходайның бер могҗизасы булгандыр, хәерле каза булсын, ди.* Ф.Тарханова. **Хәерле көн** Көндез сәлам бирү, сәламләү сүзе буларак кулланыла. *Сәламлиләр якты тәрәзәләр, Гөлләр кебек матур балалар. «Хәерле көн! Исәнмесез!» – диеп, Ишектән үк каршы алалар.* К.Булатова. *Хәерле көн! Минем исемем Азамат.* З.Хәким. **Хәерле кулдан** «Кулы җиңел булсын», «моннан соң да әйбәт сатылсын» дип теләү. *Сатканда-алганда: «хәерле кулдан»; каз өмәсеннән киткәндә: «казларыгыз икенче елга да күп булсын»; байлыгын югалткан кешегә: «кайгырмагыз маллар өчен, баш сау булса, табарбыз» --- диелә.* Р.Абдуллина. **Хәерле сәгатьтә** Юлга чыкканда яки берәр эш башлаганда, аның уңышлы булуын теләп әйтелә торган теләк. *Монысы ярый, хәерле сәгатьтә булсын, тик Толбайга зур торак пункт, район үзәге кирәкмәс иде, андый җирдә полициясе-ние була, бәладән башаяк.* З.Мурсиев. *Ярты көнне ничек кирәк алай этеп-төртеп уздыргач, Фаягөл, «хәерле сәгатьтә» дия-дия, урамга чыкты.* А.Әхмәтгалиева. **Хәерле йокы** Тыныч йокы, тыныч төн, матур төшләр теләп әйтелә. *Мин килергә булдым; ул минем кулымны кат-кат кысып, хәерле йокы теләп озатып калды.* Ә.Еники. **Хәерле сәфәр** *к.* **хәерле юл**. *Хәерле сәфәр, Солтангир абый, исән-сау йөреп кайтыгыз.* Р.Кәрами. *– Хәерле сәфәр, – дип мыгырданды Нурихан.* Н.Гыйматдинова. **Хәерле төн** 1) Төнлә күрешкән кешеләрнең берберсен сәламләве буларак кулланыла. *Тегеләр янәшәсенә килеп туктауга: – Хәерле төн! – дип кәефле генә сәлам бирде.* Б.Камалов. *Икенче көнне егет аны машинасы белән Достоевский тукталышыннан бераз китүгә үк куып җитте һәм «Жигули»ен туктатты да, ишеген ачып: – Хәерле төн, кыргый кызый! – дип елмайды.* Ә.Сафиуллин; 2) Төнлә саубуллашу сүзе буларак һәм тыныч йокы, тыныч төн теләп әйтелә. *– Хәерле төн! – диде Сәгыйть, саубуллашып.* Н.Фәттах. *– Хәерле төннәр! Иртәгә очрашканчыга кадәр, – диде әзмәвер, ишекне ныклап япканда һәм, икенче бер юлчыны ияртеп, ары китте.* Ф.Җамалетдинова. **Хәерле юл** Юлга чыкканда әйтелә торган теләк. *Ике дистәгә якын олауга капчыклар төялеп беткәч, Хәнәфи аларны тагын бер кат санап чыкты да, кечкенә блокнотына билге ясап, кулын күтәрде: – Хәерле юл, егетләр.* Г.Әпсәләмов. *Иреннәр башкача сөйлиләр: – Хәерле юл сиңа, егетем!* Г.Гыйльманов

**ХӘЕР-САДАКА** *җый. и. гар.* Хәер итеп, садака итеп бирелгән һәртөрле акча. *Күрше хакы дип, кайчандыр ат биреп торып кылган яхшылыкларын истә тотып, һичкайчан да хәер-садакасыннан калдырмады.* М.Хәсәнов. *Ил-көн, каралар элеккечә изгеләрне олылый башласалар, яңадан хәер-садака, корбан бирә башласалар, югарыдагыларның күңеле йомшар, җиргә, Акланга берninди бәла-каза, куркыныч янамас, ди.* Н.Фәттах // Хәер итеп бирелгән әйбер, ризык. *Бу хәер-садака сыныклары Әбүзәрнең тамак төбенә таш булып тыгыла, ул аларны суга манчып та йота алмый иде.* Г.Әпсәләмов

**ХӘЕРСЕЗ** *с.* **1.** 1) Уңышсыз, яхшы ягы булмаган, уңай нәтиҗәгә китермәгән, әйбәт тәмамланмаган, начар. *Әллә нинди хәерсез көн булды бүген.* З.Мурсиев. *Зиннәт үз ихтыяры белән гомерендә дә аяк атламас иде бу хәерсез почмакка, әнә шул сер тартып китерде, ахры, аны монда.* Г.Гыйльманов

2) Юньсез, тискәре сыйфатлы, әшәке, начар (яратмыйча, өнәмичә, ачуланып әйткәндә кулланыла). *Тәрәзә төбендә бөрешеп утырган теге хәерсез егет кабат күз алдына килеп басты, аның кerделе-чыктылы сүзләре искә төште.* Р.Габделхакова. *Шушы авыр заманда да авылдашларын талап яткан бит, хәерсез бәндә!* Ф.Баттал

**2.** *и. мәгъ. сөйл.* Ачулану, сукрану сүзе буларак кулланыла: юньсез кеше. *Хәерсезне юкка көттем.* Г.Ибраһимов. *Төнге юллар я бик изге кешене, я бик хәерсезне йөртә шул.* Т.Галиуллин

**3.** *рәв. мәгъ.* Уңышсыз рәвештә, начар, яман. *Минем дә иртәдән хәерсез башланган көнем кичкә кадәр шулай дәвам итте.* З.Зәйнуллин. *Әмма, моның ахыры хәерсез бетәргә мөмкин, дигән гасабилы халәт, пошынулы уйлар аны бимазалап, юл буена озата барды.* Р.Кәрами

**ХӘЕР-ФАТИХА** *җый. и. гар.* 1) Яхшы теләкләр. *Кояшлары яңа гына чыкканнарга бездән хәер-фатиха!* Ә.Еники. *– Изге хәер-фатихаң өчен рәхмәт, Фатыйма апа, Аллаһы Тәгалә сиңа да ике дөнья рәхәтен бирсен! – диде Кадерниса.* Р.Сафин

2) Фатиха, рөхсәт, ризалык; хуплау сүзләре. *Үзебезнең Хәлиуллага кияүгә чыгарга хәер-фатиханы бирсәң, миңа шул җиткән!* В.Нуруллин. *Кечкенә Илдарны күтәреп, Хәким абый белән Мәүлидә апа янына да кереп чыктылар, аларның хәер-фатихасын алдылар.* А.Әхмәтгалиева

**ХӘЕРХАҺ** *с. фар.* **1.** Теләктәш; эш-гамәлләрен, фикерләрен хуплый, карашларын яклый торган; игелекле, шәфкатьле, ярдәмчел. *Ул немецларның үзенә хәерхаһ карашларын сизде, үзен иркен тотты.* Х.Камалов. *Ләкин зиндан сакчылары да тоташ залимнәрдән генә тормый икән, алар арасында гыйсъянчы хәзрәткә хәерхаһ кешеләр табылмый калмады.* В.Имамов

**2.** *рәв. мәгъ.* Хуплап, аңлап, ышанып; яхшы, уңай. *Үзенә хәерхаһ карамаган кешеләргә дә ачу тота белмәве ярдәм иткәндер, күрәсең.* Х.Камалов. *Ләкин, хафалануы юкка булды: аңа власть әһелләре хәерхаһ карады, ни эшләсәң дә ихтыярың, тик бу болганы тизрәк буып ташла, дигәнрәк теләк белдерделәр.* З.Мурсиев

**3.** *хәб. функ.* «Яхшы, уңай мөнәсәбәттә», «уңай карыйм» дигән мәгънәдә. *Шулай итеп, мин ике иптәшнең дә иҗатына хәерхаһ.* Р.Миңнуллин. *Ә без үз чиратыбызда һәр конструктив тәкъдимгә, һәр эшкә хәерхаһ.* Р.Зәйдулла

**4.** *и. мәгъ.* Башкаларга карата уңай мөнәсәбәттә булган, яхшылык теләгән, теләктәш кеше. *Ләкин хәзерге рус хәятында зур урын тоткан төрле сәяси партияләрнең, әлбәттә, мөселман съездында да хәерхаһлары, дустлары, фикердәшләре, әгъзалары булды.* Г.Исхакый. *Икесенең чырайларында хәерхаһлар нуры бар.* Х.Камалов

**ХӘЕРХАҺЛЫ** *с. ялг. к.* **хәерхаһ 1.** *Габделнурга һәрчак ачык йөзле, хәерхаһлы әбекәйнең егетне ишек катыннан гына җибәрәсе килми иде, күрәсең.* Р.Кәрами. *Җәлләлетдин – вәкарь, хәерхаһлы кеше, ул хатыннарга каршы сугышмый, янәмәсе.* В.Имамов

**ХӘЕРХАҺЛЫК** *и.* Кемгәдер яхшылык теләү, теләктәшлек, уңай мөнәсәбәт. *Хәер, бер Ваһапов кына да түгел, ул вакыттагы башка талантлы җырчылар вә композиторлар да аның хәерхаһлыгына таянганнар.* Ш.Маннапов. *Мәңгелек Күк Тәңре хәерхаһлыгыннан ташламаса, ул әле тагын берике дистә ел яшәр сыман.* В.Имамов

**ХӘЕРХАҺЛЫК ИТҮ** *ф.* Уңай мөнәсәбәттә булу, теләктәш булу, яхшы күреп хуплау. *Аның кулы куелган документларны күрсәләр, милли кадрның үтенечләренә колак салмау мөмкин түгел, дигәндәй, югарыдагы түрәләр хәерхаһлык итәләрдер?* Ф.Яхин. *Мәрхүм Шакир әфәнде гүзәл әхлаклы вә хәлим табигатьле булып, башкаларга файда тидерү вә һәркемгә хәерхаһлык итүдән ләззәт ала.* Гасырлар авазы

**ХӘЕРХАҺЛЫ́К КЫЛУ** *ф. к.* **хәерхаһлык итү**. *Балалы кешеләргә, балаларына хәерхаһлык кылып, боларның сүзләренә карамаска кирәк.* Ә.Максуди. *Асылташлар белән бизәлгән иконаны бүләк иткән чакта нинди сүзләр әйтеп хәерхаһлык кылган иде соң әле ул?* В.Имамов

**ХӘЕРЧЕ** *и.* **1.** 1) Бик ярлы, фәкыйрь, мохтаҗ кеше. *Мөрәле Сәләхи малае бит ул, мир көтүен көткән хәерче бит ул!* М.Мәһдиев. *Рөстәмбәкнең ярсуы язгы ташу сыман әле һаман басылмаган иде, кабат кубып сүгенүен белде: – Хәерчегә якты чырай күрсәтсәң, ул ямаулык сорар, дигән атай-бабай.* В.Имамов

2) *к.* **теләнче**. *Мин бала чакта безгә көненә әллә ничә хәерче кереп әйләнә иде.* Ш.Галиев. *Хәерче чыгып киткәч, Таңсылу хикмәтле йолдызны кулына алса, ни күрсен – йолдыз нур сибеп янудан туктаган.* Ф.Яруллин

3) Байлар белән чагыштырганда, бик гади тормышта яшәүче, хезмәт хакын иң кирәк ихтыяҗларга гына тотып, тыйнак тормыш алып баручы кеше. *Җәмгыять икегә – байларга һәм хәерчеләргә бүленде.* З.Мәхмүди. *Дус-иштән дә әҗәткә җыеп булмый – бар танышлары шул: сәнгать тирәсендә кайнашучы хәерчеләр.* И.Сиraҗи

4) *сөйл.* Материаль ягы мактанырлык булмаган, гади тормышта яшәгән кешене кимсетеп тиргәү сүзе буларак кулланыла. *Ах, син, урам тастымалы, себерке, хәерче, исән чакта югал күземнән!* К.Тинчурин. *Кара син аны, кешене туктатып торган була тагы, хәерче!* М.Галәү

**2.** *с. мәгъ.* 1) Теләнеп йөри, садака исәбенә яши торган. *Шул ук көйне әкиятче Сираҗи уйный, хәерче малай да шуны җырлый, каз өмәсендә дә кабатлана, сугышка чыгып китүче солдатлар да шул көйгә иңрилəр.* Р.Батулла. *Юл буенда, имчәк баласын кочаклап, сәләмә киемле хәерче хатын утыра.* Р.Габделхакова

2) Ярлы, авыр, материаль яктан кыенлык кичергән. *Сугыштан соңгы авыр, хәерче елларда авыл тирәләрендә яхшы, нәселле атлар, айгырлар бик аз иде.* А.Хәсәнов. *– Һай, бигрәк хәерче дә заманга туры килде безнең яшьлек! – дип искә ала иде үткәннәрне Маратның әнисе.* Д.Гыйсметдин

3) Начар, ярлы, сәләмә, иске, заманча булмаган, башкаларныкыннан сыйфаты һ.б. белән аерылып торган. *– Районга нишләп бу хәерче киемнән барырга тиеш әле мин! – дип сукранды ул үзалдына.* З.Хөснияр

**3.** *рәв. мәгъ.* Начар, ярлы, материаль яктан кыенлыкта. *Заманча яши авыл, тик хәерче яши.* З.Мәхмүди. *Алар бик хәерче киенгәннәр.* Г.Каюмов

◊ **Хәерче бет(е)** «Син беркем дә түгел», «синең фикереңне беркем дә сорамый» дигән мәгънәдә, кимсетеп, кешегә санамыйча, дәрәҗәсен төшереп әйтелә. *Нух Галләмнең иләмсез каты кулы Солтанның муен тамырына кагылып ала: – Тик кенә утыр, хәерче бете!* Г.Ахунов. *Нәрсә кыланасың инде, хәерче бет!* Н.Гыйматдинова. **Хәерче көненә калу** Тәмам бөлү, зур мохтаҗлыкка дучар булу. *Туганнарым хәерче көненә калып, көтүгә ялланганнар, дип хафаланма.* А.Хәлим. *Чыгырдан чыгарырлык кайгы-хәсрәт кузалланмады, чәчләрне йолыккаларлык авыр югалтуларга тарымады, булганыннан колак кагып, хәерче көненә калып, тормыш төбенә төшмәде яисә кичермәс гөнаһлар кылмады, дүрт саны төгәл, сау-сәламәт.* К.Кара. **Хәерче танау** Материаль хәле әллә ни мактанырлык булмаган, үзеннән күпкә ярлырак кешегә карата кимсетеп, яратмыйча әйтелә. *– Мәгънәсез ахмак! Хәерче танау! Әдәм рәтле каршы ала да белми, имансыз! – дип сукранды моңарчы түзеп торган Кысык Минҗан.* Г.Ахунов. *Хәерче танау! Гарифҗанга нигә кагылдың?* Н.Яһудин

**ХӘЕРЧЕЛӘНДЕРҮ** *ф.* Хәерче хәленә китерү, бөлгенлеккә төшерү. *Шуның белән үзебезне рухи яктан да бөтенләй диярлек хәерчеләндергәнбез.* И.Әмирхан. *Халыкның күпчелек өлешен без бик нык хәерчеләндердек шул.* Р.Вәлиев

**Хәерчеләндерә бару** Торган саен күбрәк хәерчеләндерү. *Анадолу игенчесенең үз җиреннән алган барлы-юклы уңышын аз гына файда белән булса да сатарлык мөмкинлеге булмау, шулай ук юлларның төзексезлеге халыкны торган саен хәерчеләндерә бара.* М.Галәү

**Хәерчеләндереп бетерү** Тәмам хәерчеләндерү

**ХӘЕРЧЕЛӘНҮ** *ф.* 1) Хәерчелеккә төшү, хәерчегә әйләнү, фәкыйрьләнү, мохтаҗлыкка төшү, бөлгенлеккә төшү. *Кемнәрдер хәерчеләнде, хәтта ачлыктан-мохтаҗлыктан Ходай хозурына китеп барды, ә кемнәрдер... череп баеды.* Ә.Рәшит. *Ил мөлкәтен дөрес бүлмәделәр: кемдер баеды, кемдер хәерчеләнде.* З.Хәким

2) Хәерчегә сабышып сорану, хәерче төсле гел нидер сорау. *[Гали хәзрәт] зур биналар салды, хәерчеләнеп акча җыйды, Истанбул, Мисыр күргән яңа тип мөгаллимнәр китертте.* Г.Ибраһимов. *Республикабыз бик баеды бит, юбилейга дигәндә – хәерчеләнәбез, идарәбез хәерче кебек соранып йөрергә, теләнергә мәҗбүр була.* Х.Туфан

3) Рухи яктан ярлылану, бушау, рухи кыйммәтләрне югалту. *Рухи экология – матди байлык бәрабәренә күңелләрнең хәерчеләнүе мәсьәләсе язучының «Танкист» повестенда гаять калку итеп гәүдәләндерелә.* Кызыл таң. *Әнине озаткач, рухи яктан хәерчеләнеп, бушап калдым.* Шәһри Казан

4) *күч. хуплм.* Саран кешегә карата «аңа карап кына байлыгың кимемәс», «булганы азаймас, бетмәс» дигән мәгънәдә әйтелә. *– Бер-ике капчык бәрәңгең кимегәннән хәерчеләнмәссең, – ди икән теге хатын.* Н.Харисова. *Кысма инде, бер папирос белән генә хәерчеләнмәссең.* З.Мәхмүди

**Хәерчеләнә бару** Торган саен күбрәк хәерчеләнү. *Яшәү рәвешебез елданел рухи яктан хәерчеләнә бара төсле миңа.* А.Хәсәнов. *Әнә мине озатып килүче көтүчеләр дә авыр яшәүләренә, тормышларының көннән-көн хәерчеләнә баруына бик тә зарландылар.* Н.Сәйяр

**Хәерчеләнә башлау** Хәерчеләнү билгеләре сизелү, күренү. *Көнбатышта кеше хәерчеләнә башласа, байларның керемнәрен фәкыйрьләргә бүлә*

*торган салым механизмнарын эшкә җигәләр.* Татарстан яшьләре

**Хәерчеләнә бирү** Хәерчеләнүен дәвам итү. *Әйдә, хәерчеләнә бирсеннәр, дип сөенергә кирәкми, чөнки алар белән бергә илнең моңарчы фәкыйрьлектә яшәгәннәренең дә хәле яманлана бара.* Татарстан яшьләре

**Хәерчеләнә төшү** Бераз хәерчеләнү; тагын да хәерчеләнү. *Хәерчеләнә төшкәнбез: агымдагы елның 11 аенда очын очка ялгап баручылар саны 10 процентка арткан.* Әлмәт таңнары

**Хәерчеләнеп алу** Бер арада, кыска вакытка хәерчеләнү. *Бер генә нәрсә тынычландыра: 1998 елгы кризис чорында да ил халкы күзгә күренеп хәерчеләнеп алган.* Татарстан яшьләре

**Хәерчеләнеп бетү** Тәмам, бик нык хәерчеләнү. *Әңгәмәне тәмамлар алдыннан Беренче аталарча җылылык белән сорап куйды: – Акчаң җитәме? Хәерчеләнеп бетмәдегезме?* Р.Мирхәйдәров

**Хәерчеләнеп йөрү** Әле, хәзерге моментта хәерчеләнгән хәлдә булу; озак вакыт дәвамында хәерче хәлдә булу. *Без дә кешедән сорап алган, хәерчеләнеп йөргән юк.* Р.Камал

**Хәерчеләнеп калу** Нинди дә булса вакыйгадан, хәлдән, вакыттан соң хәерчеләнү. *Әмма түбәсез хәлендә хәерчеләнеп калган туган йорты аны кертергә теләмәде.* Ф.Яхин. *Төбәкләрдәге кече эшмәкәрлек тә хәерчеләнеп калган сатып алучылар аркасында аяк сузачак.* Туган як

**Хәерчеләнеп яту** *сөйл.* Әле, хәзерге вакытта хәерчеләнгән булу; озак вакыт дәвамында хәерче хәлендә булу. *Кеше череп баеганда, череп, хәерчеләнеп ятар өчен, төннәр буе йокы күрмичә каләм тирбәтүне мин фәкать кояш баеганнан соң сайрарга тотынган сандугач моңына гына алмаштыра аламдыр шикелле.* Ә.Гаффар

**ХӘЕРЧЕЛЕК** *и.* 1) Ярлы тормыш, фәкыйрьлек, мохтаҗлык, бөлгенлек. *Өйдәге күзгә бәреп торган хәерчелек салым инспекторының кәефен кырды.* З.Мәхмүди. *Иң матур тостны Гарифулла Нигъмәтуллин әйтте: – Күп нужалар, хәерчелек, ачлык күреп тә татарлыгын югалтмаган үзебезнең татар халкы өчен тәкъдим итәм мин бу тостны.* З.Зәйнуллин

2) Кияргә кием, ашарга ризык булмау; тормыш кирәк-яраклары җитешмәү, ачлык, юклык, мескенлек. *Ачлыктан, хәерчелектән үлүчеләр дә күп була.* Л.Хәмидуллин. *Өс-башы иске, хәерчелеге баштан ашканлыгы әллә каян күренеп тора.* М.Хәсәнов

3) Материаль ягы начар булу, артта калганлык, мохтаҗлык (ил, республика, өлкә һ.б.ш. тур.). *Илгә килгән сугыш афәтләре һәм сугыштан соңгы ачлык, хәерчелек елларында бик авыр хәлгә калган чакларым да булмады түгел, булды.* Г.Галиева. *Чикнең теге ягында – ачлык, изү, изелү, золым, хокуксызлык, хәерчелек.* В.Юныс

4) *күч.* Рухи ярлылык; күңел байлыгы, рух байлыгы булмау, гамьсезлек. *Шуңа кадәр хөкүмәтебез чаралар күрмәсә, кешеләр рухын хәерчелек котә.* И.Юзеев. *Күңел хәерчелеге бүләкме, җәзамы – миңа, мәсәлән, мәгълүм түгел.* З.Хәким

◊ **Хәерчелек басу** Хәерчелек көчәю, хәерчелек таралу. *Әмма дөньялар инде тыныч түгел иде, илне, авылны хәерчелек басты, кешеләр явызланганнан-явызлана бардылар, дин онытылды, муллаларның сүзе кирәксезгә чыга башлады.* Ф.Бәйрәмова. **Хәерчелеккә бату** *к.* **хәерчелеккә калу**. *Хәерчелеккә баткан, күз яшьләренә чыланган, аһзар белән тулган ил елый.* А.Алиш. *Хакимият вертикале булсын дип көрәштек тә чынлыкта менә ниләр алдык: түләнмәгән эш хаклары, тарифлар арту, инфляция һәм дә, төбәкләр хәерчелеккә батып ятканда, финансларны Мәскәүгә суыртуны...* Р.Юныс. **Хәерчелеккә калу** Бөлгенлеккә төшү, материаль яктан авырлыклар кичерү. *Кем әйтеп кем ышаныр: кибеттәге өч тиенлек малай башың белән, бөтен дөнья хәерчелеккә калганда, баедың да киттең.* К.Тинчурин. **Хәерчелеккә төшерү** Ярлыландыру, материаль хәлен, яшәү шартларын начарайту. *Соңгы ун-унике ел буе барган ирекле базарга күчү дә халыкның бик зур өлешен моңа кадәр булмаган хәерчелеккә төшерде.* Р.Зарипов. **Хәерчелеккә төшү** *к.* **хәерчелеккә калу**. *Соңгы орышта болар хәерчелеккә төшкәнче, анадан тума калганчы сугышканнар, беренчеләре яланаякка чабата киеп, икенчеләре шәрә тәнгә галстук тагып торып калган...* А.Тимергалин. *Хикмәт хаҗи бөлә, хәерчелеккә төшә, бер башкорт өендә үлә.* Р.Рахман. **Хәерчелек сазлыгына бату** *к.* **хәерчелеккә калу**. *Тормышыбыз менә арулана, менә арулана дип, өмет йолдызына күз текәгән халык көннән-көн хәерчелек сазлыгына бата бара.* Н.Әхмәдиев. **Хәерчелек сөрү** Хәерче хәлендә булу, юклыкта яшәү, матди ягы җитеш булмау. *Шагыйрьләрнең язмышлары шулмы – Яшим җирдә хәерчелек сөреп. Фирдәүсиләр шулай китеп барган, Китаплары калган ядкәргә*! Ф.Яхин. **Хәерчелектә калу** *к.* **хәерчелеккә калу**. *Юк, аңа гына түгел, бар авылның минем кебек чарасызлыкта калуына, рухи, матди хәерчелектә калып, шуннан чыга алмавына йөрәгем күбрәк әрни минем.* Н.Гариф. **Хәерчелектә калдыру** *к.* **хәерчелеккә төшерү**. *--- әйтеп бетергесез катлаулы дини-мифологик системалардан, хорафатлардан тулысынча баш тартып, «большевистик тәрбия» ил-җәмгыятьне, бигрәк тә яшьләрне рухи яктан хәерчелектә калдырды, коточкыч упкын алдына китереп терәде!* Ф.Урманче. *Цивилизацияле капиталистик (онытмыйк, нигез сүз – «капитал») мөнәсәбәтләр булмау сәбәпле, «кыргый базар» күпчелек хезмәт ияләрен хәерчелектә калдырды; азсанлы бер төркем фантастик байлыкларны кулга төшерде, күпләр фәкыйрьлекнең чигенә терәлде.* Р.Фәйзуллин. **Хәерчелектән баш чыкмау** Мантый алмау, бик озак хәерче хәлендә булу, мохтаҗлык кичерү. *Шул җимереләм-җимереләм дип торган өйгә кайтачак, рәтле-башлы эш табуы икеле, көн ярымга тиен ярым өчен йөрер селкенеп, хәерчелектән башы чыкмас, я эчкечелеккә бирелер, я тагын берәр юләрлек эшләп, кире монда килеп эләгер.* К.Кара. *Хәзер менә хәерчелектән баш чыкмый.* Р.Габделхакова. **Хәерчелектән чыгу** Матди хәлен яхшырту, яхшырак яшәп китү, мохтаҗлык кичерми башлау. *Ләкин анасы ярдәмендә Тимучин акрынлап хәерчелектән чыга.* Р.Батулла. *Татар нефте акча булып тоташтан агып торганда да ил хәерчелектән чыга алмады.* Р.Харис

**ХӘҖҖАМ** *и. гар. иск.* Кан алучы; хиҗамә ясаучы. *Бәрдазан тәнендән кан алдырса, хәҗҗам аның тамырынә ништәр урса ---.* К.Гали. *Бер хәҗҗам пәйгамбәр галәйһиссәламгә кан алырга килде.* К.Насыйри

**ХӘЗЕР** *рәв. гар.* 1) Шушы вакытта, шушы моментта, шушы арада. *Аның күңелендә хәзер бер генә ачык уй-фикер дә, бер генә билгеле теләкомтылыш та юк иде.* Н.Фәттах. *Ә менә*

*хәзер, үзенә туп-туры атлаучы дин әһелен күреп, югалып калгандай булды.* М.Кәбиров

2) Әле генә, яңа гына, бая гына, күптән түгел. *Рәхмәт, миңа ясамагыз, әнәсем килми, хәзер генә эчтем.* Г.Кутуй. *Хәзер генә киттеләр әле, бәлки, куып җитә алырсыз.* Ялкын

3) Тиздән, бик якын арада, бераздан. *Хәзер, хәзер киләләр, диген, бар, акыллым.* К.Тинчурин. *Хәзер, әти, менә бу чиләкне генә тутырыйм да.* М.Мәһдиев

4) Шушы моменттан, шушы моменттан алып. *Ул Мостафинны штабка дәшеп кертә һәм, ризалыгын да сорап тормастан: – Сез хәзер штабның өлкән писаре, – ди.* М.Шабаев. *Шикләнмичә теләсә нинди сереңне чишә аласың хәзер, туганым.* М.Әмирханов

5) Бүгенге көндә, әлеге вакытта. *Мин хәзер шәкерт кеше, мәдрәсәгә йөрим.* Г.Бәширов. *Хәзер ул район үзәге түгел, һәм анда автобуслар йөрмидер, юллары да асфальт түгелдер, дип кисәттем.* А.Тимергалин

6) Бик тиз, шундук, шул минутта, озак тормастан, капыл гына, кинәт. *Юристка задание бирсәм, хәзер оештырыр!* Т.Галиуллин. *Безнең илдә шулай шул, артык киң күңелле булырга да ярамый, хәзер ыштансыз калдырып китәләр.* Х.Ибраһим

7) *сөйл.* Иронияле җөмләләрдә инкяр итүне, каршы килүне куәтли. *Хәзер, син исерек янына төште, ди!.. Түбәнсенде, ди!..* А.Хәлим

**ХӘЗЕ́Р** *хәб. сүз гар.* Кем тарафыннан булса да алдан хәстәрләнгән, файдалану өчен яраклы хәлгә китереп куелган; әзер. *Аның алдында васыятьләрен дә әйтте: сыеры белән кәҗәсен ике мөәззин белән ике муллага фидия итәргә, ди, әллә ничә елдан бирле җыйган акчасы бар икән, аны чәчүенә, ди, кәфенлегә күптән хәзер икән.* Г.Ибраһимов. *Алар инде күптән хәзер: намазлык, чолгауларны күптән хәзерләп куйганнар.* Г.Камал

**ХӘ́ЗЕРГӘ** *рәв.* 1) Шушы моменттан алып, беркадәр вакыт дәвамында, бераз вакыт, вакытлыча. *Яңа хуҗа өчен йорт салырга кирәк булыр, ә хәзергә Наилә апада торып торырга туры киләчәк, дип килештеләр.* М.Маликова. *Миңа хәзергә урамга чыгарга ярамый.* М.Хуҗин

2) Әлеге вакытта, әлегә, билгеле бер вакытка кадәр; вакыты җиткәнче. *Кай тарафка очарга белми торганда, ир белән хатын кыяфәтендәге ак халатлы ике фәрештә килеп чыкты һәм: – Ашыгып кердең, синең урының хәзергә монда түгел, – дип, тәнем кысылып калган караңгы коридорга кире озаттылар.* Н.Әхмәдиев. *Хәзергә әле әни авылда калып торды.* М.Хәсәнов // Әле, хәзер, шушы моментта, шушы мизгелдә. *Ә хәзергә ял итегез, күңел ачыгыз, сезгә комачауламыйм.* Ә.Гадел

3) Бүгенге көндә. *Дөрес, хәзергә кабул итәр нәрсә юк югын, тик анысы зур бәла түгел, өметне өзмәскә кирәк: ике-өч елдан безнең дә берәр объект төзелеп бетәр әле.* Н.Әхмәдиев. *Үзең беләсең: ныклы терәгем дә, байлыгым да юк хәзергә.* А.Әхмәтгалиева

**ХӘ́ЗЕРГӘЧӘ** *рәв.* Бу көнгә кадәр, шушы көнгәчә; шушы вакытка кадәр. *Мәгәр Әгъләм абыйның кылган яхшылыгы, изгелеге хәзергәчә халык телендә, зиһенендә, хисендә.* Т.Галиуллин. *Мине тетрәндергәне, хәзергәчә истә калганы апаның тонык, төссез күзләре иде.* Н.Гариф

**ХӘ́ЗЕРГЕ** *с.* 1) Бүгенге көндәге, шушы чордагы, бу вакыттагы. *Ә хәзерге замандашларыбыз арасында рухи гарипләр – акча коллары күбәюен беләбез.* И.Юзеев. *Ул чагында, бәлки, дөньяданиләр барын ап-ачык күзаллый да алыр иде, читтән торып, үзенең хәзерге халәтен аңларга тырышыр, мәгънәсенә төшенергә азапланыр иде.* А.Вергазов

2) Шушы чорга караган, шушы чор үзенчәлекләренә җавап бирерлек. *Хәзерге әдәби телдә исем фигыль -у/-ү кушымчасы белән ясала һәм процессны атап, процесс исемен белдереп килә: бару, килү, йөгерү, көлү, сөйләү h.б.* Ф.Хисамова. *Үткән чорларга хас теоретик принциплар, анализ юллары әдәбият тарихын һәм хәзерге әдәби күренешләрне берьяклы аңлатуга китерә.* Ә.Закирҗанов

3) Бүгенге көндәге; бүгенге көндә булган, шушы вакытта яши торган. *Шәригать нигезендә ирләрнең ике-өч хатын белән торуы гадәти хәл саналса да, Көектә, хәзерге Фарук мулланың бабасыннан башка, берәүнең дә ике хатынлы булуын хәтерләмиләр.* Г.Галиева. *Бу йорт безнең хәзерге рәискә тыныч кына яшәргә ирек бирми, аңа Сәлимгәрәй абыйның тизрәк бу якты дөньядан китүе, йортның бушавы мөһимрәк.* Д.Салихов

4) Әлеге мизгелдә, әлеге вакытта, сөйләү моментында. *Анда аның хәзерге минутта уйлаган уйлары җөмлә рәвешендә экранда күренәләр иде.* З.Мәхмүди. *Менә хәзерге минутта да син мине яратканга, минсез яши алмавыңа үземне гаепле итеп сизәм.* З.Хәким

5) Заманча, үз чорының таләпләренә җавап бирә торган, үз чоры югарылыгында булган. *Язучы җинаятьне ачуда хәзерге фән-техника казанышларыннан файдалануга зур игътибар бирә.* Ф.Мусин. *Хәзерге фәндә әйтелгәнчә, әлеге факторлар халыкның аңы аша үтеп кенә аның аерым сыйфатларын активлаштыра, аларны беркетеп, символлаштыра, үзләренең бердәмлеге турында күзаллауны булдыра, һәм алар барысы да этник төркемнәрдә тупланып, аеруча ачык чагыла.* М.Хәсәнов

6) *лингв.* Эш яки хәлнең башкарылуы сөйләп тору вакытына туры килүен яки аның даими булуын күрсәтә торган заман. *Хаталар күбесенчә -учы/ -үче кушымчалы хәзерге заман сыйфат фигыльләрен куллануга карый.* Р.Юсупов. *Хәзерге заман хикәя фигыль даими, гадәти, кабатлаулы эш-хәлләрне белдергәндә, әлеге мәгънәне көчәйтеп җибәрә торган һәрвакыт, еш, гадәттә кебек лексик чаралар кулланыла.* Л.Гыйлаҗева

**ХӘЗЕРЛӘНҮ** *ф. к.* **әзерләнү**. *Бу нәрсәләрне эшләп барганда, хәзерләнгән бланк кәгазьләре буенча кайсы вакытта нәрсә эшләнгәнен һәм ничек эшләнгәнен аермачык рәвештә язып барырга кирәк.* Һ.Такташ. *Аның күңеле, ахрысы, эчтән генә бу хәлгә көз буе, кыш буе хәзерләнгән иде – узган көз үк инде кызый үзенең хисләрендә әллә нинди зур, котылгысыз борылыш булганын сизгән иде.* М.Мәһдиев

**Хәзерләнә башлау** *к.* **әзерләнә башлау**. *Газинур үзе дә, мәктәпкә хәзерләнә башлаган кызлары да урман яланында калдырып кайткан бүре малае турында онытып та киләләр иде бугай.* А.Хәсәнов. *Әйбәтләп кенә бүген йокларга да, иртүк торып, имтиханга хәзерләнә башларга кирәк.* Н.Әхмәдиев

**Хәзерләнә төшү** *к.* **әзерләнә төшү**. *Немец дәүләтенең министры, әлбәттә, ата фашист, ул Шәфи Алмаслардан акыллырак, мәкерлерәк, аның янына, билгеле, хәзерләнә төшебрәк барырга кирәк.* Г.Әпсәләмов

**Хәзерләнеп алу** Тиз генә хәзерләнү. *Лекциядән соң китапханәгә кереп, киләсе семинарга хәзерләнеп алдык та, Герцен урамына чыгып, консерваториягә юл тоттык.* М.Юныс

**Хәзерләнеп бетү** *к.* **әзерләнеп бетү**. *Имтиханга хәзерләнеп бетү белән, Фәнияр аларга хәбәр иттерде.* Ф.Яруллин. *Бәлки, безнең «күрсәткечләр» әллә кайчан хәзерләнеп беткәндер, уртак Сталинның яисә Бухаринның өстәле өстендә әллә кайчан ятадыр инде.* Ф.Сафин

**Хәзерләнеп җитү** *к.* **әзерләнеп җитү**. *И Ходаем, кунаклар килер вакыт җиткән, безнең табыннар да хәзерләнеп җитмәгән.* Г.Камал. *Кышка бал хәзерләнеп җитте, инде баштан кайгы китте, дигәндә генә, әлеге бабай белән теге шаян малай, килеп, баллы кәрәзләрне кистеләр дә алып киттеләр.* А.Алиш

**Хәзерләнеп йөрү** *к.* **әзерләнеп йөрү**. *Алдан ук моңа хәзерләнеп йөргән кебек ул.* Х.Камалов. *Беркөнне Рифат мунча керергә хәзерләнеп йөргәндә, капкадагы кыңгырау шалтырады.* Ә.Хәсәнов

**Хәзерләнеп килү** *к.* **әзерләнеп килү**. *Мәфтуха барып кайтканнан бирле Гөлбану моңа хәзерләнеп килә иде.* Г.Ибраһимов. *Әмма күп еллар буе хәзерләнеп килгән, зур өметләр багланган бу вакыйга булмый кала.* Б.Гыйззәт

**Хәзерләнеп кую** *к.* **әзерләнеп кую**. *Ашамлыклар, кирәк-яраклар барысы да, атна-ун көнгә дип, алдан хәзерләнеп куелган.* Г.Гомәр. *Чөнки бу җыелышның алдан ук хәзерләнеп куелган кәмит икәнлегенә инде шигем калмады.* В.Имамов

**Хәзерләнеп тору** *к.* **әзерләнеп тору**. *Әйе, әнкәй, хәзерләнеп торырга куштылар.* Т.Гыйззәт. *Алдан берәр кеше җибәреп әйттерсәгез, хәзерләнеп торырбыз.* Г.Камал

**Хәзерләнеп яту** *к.* **әзерләнеп яту**. *Берничә еллар буенча бөтен дөньясын ташлап, университетка керер өчен аттестатка хәзерләнеп яткан Җиһангир күрсәтүе буенча биш сумга студент тапты да укырга чумды.* Г.Ибраһимов

**ХӘЗЕРЛӘҮ** *ф. к.* **әзерләү**. *Ялгышмасам, Муса шул вакытта Габдулла Тукай әсәрләренең редакциясен карап, басмага хәзерли иде шикелле.* Р.Мостафин. *Икенче көнне сәгать иртәнге сигездә без диңгезчеләр хәзерли торган училищеның ишеге ачылганын көтеп утыра идек инде.* М.Юныс

**Хәзерләп алу** *к.* **әзерләп алу**. *Гадәтенчә, тын, бик тын гына моңлы көй көйләп, ашарга хәзерләп алгандыр.* Ф.Сафин

**Хәзерләп ату** Ашыгып, тиз-тиз хәзерләү. *Эштән кайткач, тиз генә салат әзерләп атты*

**Хәзерләп бетерү** *к.* **әзерләп бетерү**. *Рөстәм дәресләрен хәзерләп бетерүгә, әби аңа һәр кич төрле-төрле көйләр җырлап җибәрә.* Г.Кутуй. *Ә районга хисап бирер көн җиткән, кичекмәстән отчётны хәзерләп бетерергә кирәк.* Н.Әхмәдиев

**Хәзерләп җиткерү** *к.* **әзерләп җиткерү**. *Йөрәгенең бу авырттыргыч ярасын вакытлыча гына булса да онытып тору өчен, тизрәк батальонга китеп эшкә чуму, солдатны һәм кирәкле командирларны тизрәк хәзерләп җиткереп, бу убыр оясыннан тизрәк үзебезнең якка чыгып китү генә бердәнбер чара булып күренде аңа.* Ш.Маннур. *Малга читтән азык ташымыйча, үзләре хәзерләп җиткерде.* Кызыл таң

**Хәзерләп йөрү** *к.* **әзерләп йөрү**. *Казанга китәр алдыннан документлар хәзерләп йөргәндә, район гәҗите редакторы Ибраһим Солтанович Дәүләтшин очрады.* Н.Әхмәдиев

**Хәзерләп калдыру** *к.* **әзерләп калдыру**. *Бакчаның җимешен җыйгач та, киләчәк ел өчен көздән бакчаны хәзерләп калдырырга кирәк.* К.Насыйри

**Хәзерләп килү** *к.* **әзерләп килү**. *Ул шул бердәнбер кызы Хәдичәнең сәгадәте өчен, аны мәхдүмнән аерып алуны, шул ун ел тәрбия кылып, кияү итеп хәзерләп килгән мәхдүмнән аерып алуны уйларга тотынды.* Г.Исхакый

**Хәзерләп кую** *к.* **әзерләп кую**. *Кортларны кышка да, оядагы артык рамнарны алып, тишек-тошык җирләрен нык томалап, җылытып хәзерләп куярга кирәк.* А.Хәсәнов. *Аннары безнең олуг ханга хәзерләп куйган хикмәтле әйберебез бар – утчагыр.* М.Хәбибуллин

**Хәзерләп тору** *к.* **әзерләп тору**. *Монда халык җыелып, бер бозауны корбан өчен хәзерләп тора иделәр.* Ф.Яхин. *Ләкин югары көчләр алда хәзерләп торганнар икән аңа сынауны.* К.Кара

**Хәзерләп яту** *к.* **әзерләп яту**. *Юкә кисүчеләр, берәм-берәм агачлар арасыннан чыгып, аш хәзерләп ятучы Рөстәм тирәсенә җыела башладылар.* Һ.Такташ. *Атаклы драматургыбыз Таҗи Гыйззәтнең «Наёмщик» музыкаль драмасындагы Гөлйөзем образын икенче вариантта хәзерләп ятабыз.* Казан утлары

**Хәзерли башлау** *к.* **әзерли башлау**. *Менә Нургали туган, фермага килгәч, абзар-кура тирәләрен рәтләп җибәрде, кыш чыгарлык азык хәзерли башлады, инде үзегез күрәсез, өч-дүрт ел эчендә малларыбызның баш саны сугышка хәтледән узып та китте.* Ә.Еники. *Менә сәламәтләнеп чыксын да, дәресләрегезне бергә хәзерли башларсыз, ярыймы?!* Ф.Тарханова

**Хәзерли тору** Алданрак хәзерләү. *Син дә аңарчы тиешле кешеләрне күреп, кирәкле материалларны хәзерли тор.* Т.Гыйззәт. *Бу инде киләчәк укучыларның күңелләренә шигъри орлык салып кую, журналның яңа буын укучыларын хәзерли тору дип бәяләнергә хаклы.* Р.Миңнуллин

**Хәзерли төшү** Тагы да бераз хәзерләү. *Печән хәзерли төшәргә кирәк, былтыр да җитмәгән иде бит.* Идел

**ХӘЗЕРЛЕК** *и. к.* **әзерлек**. *Юлбасарлар аларны алдан ук көтеп, сагалап торып, нык хәзерлек белән каршы алганнар.* А.Хәсәнов. *Хәзерлеге яхшы булгандырмы, Казанда калу теләге чиксез зурлыктанмы, ул шундый тырышып укыган булып чыктымы – гимназияләрдән килгән бай малайларын да уздырып, йөзләгән кеше арасыннан бушлай уку хокукы бирә торган өч стипендиянең берсенә лаек дип табылды.* Р.Мөхәммәдиев

**ХӘЗЕРЛЕКЛЕ** *с. к.* **әзерлекле**. *Савыккач, алар арасыннан иң нык, иң хәзерлекле егетләрне сайлап алып, яңа төр артиллерия установкалары – «Катюша»лар белән эш итәргә өйрәтәләр.* Г.Мөхәммәтшин. *Әмма дә ләкин каршы як хәзерлекле булып чыкты.* Т.Галиуллин

**ХӘЗИНӘ** *и. гар.* 1) *тар.* Дәүләт башлыгының, хөкемдарның карамагындагы акча, алтын-көмеш һ.б. кыйммәтле нәрсәләр формасында тупланган байлык; казна. *Безнең җиребездә аяклы мал бик күп; без хәзинәгә дә шуның белән салым түлибез ---.* Г.Гобәйдуллин. *Хәзинә сакчысы, бар, казнадагы зөбәрҗәт ташларны кара.* А.Гадел

2) *иск.* Берәр оешма, берләшмә, гаскәр һ.б.ш. зат акчасы, бюджеты, кассасы. *Бу хәл Төркиянең хәзинәсенә начар тәэсир итте.* Г.Гобәйдуллин. *Әлбәттә, хәзинәдә әле Салавычтан ук төйнәп чыккан байлык-нигъмәтнең зур өлеше барыбер калган иде.* В.Имамов

3) Кемнең дә булса милке, малмөлкәте, дәүләте, байлыгы. *Өс киемнәрен генә ала да бөтен булган хәзинәсен калдырып китә дә бара.* С.Поварисов. *– Җир тетрәсә, хәзинәң туфрак астында калып харап була лабаса ! – ди.* Т.Әйди

4) Берәр кая яшерелгән, күмелгән алтын-көмеш, асылташлар, акча яисә

нинди дә булса кыйммәтле әйберләр. *Әһ-һәәә, белдем инде... алар берәр күмелгән хәзинә беләләрдер...* Г.Гобәй. *Мин сезгә хәзинә яшерелгән картаны һәм аның буенча байлыкларны табу юлын күрсәтәм.* Г.Каюмов // Гомумән, шундый һәртөрле затлы әйберләр. *Кайсыдыр явызы шушы хәлне белеп торган, тегеләр эштә чагында, ишек төбендәге кимендә аю чаклы этне, заманның гаять нык, хәйләле йозакларын үтеп өйгә кергән, нәни сейфны барча хәзинәсеннән бушаткан.* Р.Фәизов. *Кубрат ханның бай хәзинәсен күргәч таң калуымны, тәмам ни кылырга белми, һәр хәзинәне тотып карарга омтылуым турында язмыйм – моны бер сүз белән генә аңлатып булмый.* М.Хәбибуллин

5) Кирәк вакытта тоту өчен әзерләп куелган нәрсә, запас. *Галим-голәмәнең даими хезмәттәшлек итү турындагы ялынычын ул кире кага, «кара энергия» янчыгын хәзинә урынына тота...* А.Тимергалин. *Ләкин алар – ахыр чиккә дип төйнәп куйган мая; Нәҗметдин хаҗиның әлеге хәзинәне җилгә чыгарып җилгәргә исәбе юк иде.* В.Имамов

6) Кешеләргә кирәк булган табигать байлыклары, файдалы казылмалар һ.б.ш. *Яңа гына тәпи йөри башлаган кече кызлары белән бергә кояшлы, җиләкле җәйнең озын көннәрен урман кочагында үткәрергә, кырык эшен кырык якка ташлап булса да, елның шушы фасылында мул итеп табигать хәзинәсе җыеп калырга күнеккән телсез-чукрак Гамиләсе дә аларга ияргә торган иде.* М.Садыйков

7) Милли-мәдәни байлык, рухи байлык, әдәби, музыкаль һ.б.ш. байлыкларның җыелмасы. *Шуңа да аның иҗаты яңа татар әдәбиятының нигез ташы, аның алтын хәзинәсе булып санала, халкыбызның рухи азыгы, илһам чыганагы булып тора.* Г.Мөхәммәтшин. *Димәк, бүгенге көн кешеләрен, үз замандашларыңны дулкынландырырлык итеп язу өчен, безгә тикле яшәгән бабаларыбыз калдырган хәзинә мирасны да, бүтән халыклар әдәбиятлары казанышларын да тирәнтен үзләштерергә, бүгенге талант ияләренең иҗатларын да яхшы белергә тиеш булабыз.* М.Вәлиев

8) Зур кыйммәткә, аеруча зур әһәмияткә ия булган билгеле бер саллы хезмәт, музыкаль, әдәби әсәр, шедевр һ.б.ш. *Аның 1878 елгы татар крестьяннары восстаниесе турындагы хезмәте дә – тарихчылар өчен зур хәзинә.* М.Мәһдиев. *Байлык – бер күнлек, ә синең язганнарың – мәңгелек хәзинә, Гөлфия Хан.* Н.Гыйматдинова

9) Истәлек, хатирә, күңел җәүһәре. *Ә менә көннәр буена самавырыннан аерыла алмаган Атбакат кушаматлы шушы Бибикамал әбинең хәтер сандыгында моңа кадәр без белмәгән, ишетмәгән никадәр хәзинә ята булып чыкты.* Н.Әхмәдиев

10) Кем өчендер аеруча кадерле, яшәвенең яме, мәгънәсе булырлык кеше; тормышындагы бик кирәкле, бик мөһим кеше. *Бала бит ул – адәм баласы өчен иң зур хәзинә.* Р.Мөхәммәдиев. *Якын дуслар булу аз, димә, Җан дуслар ул – үзе хәзинә.* С.Әхмәтҗанова // Билгеле сыйфатлары белән кем өчендер бик мөһим, кадерле, затлы саналган, зур байлыкка тиң кеше, әйбер. *Хатын түгел, хәзинә икән син!* Н.Гыйматдинова. *Мондый хәзинә кулына эләгүгә, Килмешәкнең шатлыгы эченә сыймый – авызы ерыла.* К.Җәмит

11) Билгеле бер телдәге сүзләр җыелмасы; сүз байлыгы, лексик байлык. *Тел хәзинәсенең төп асыл бакчасы, әлбәттә, әдәбият, беренче чиратта классик әдәбият.* Р.Фәйзуллин. *Хезмәте буенча Даниягә күп йөрергә, күп кешеләр белән очрашырга туры килә: ул фәнни институтта эшли, халыкның тел хәзинәләрен җыю белән шөгыльләнә.* М.Маликова

12) Кешене башкалардан аерып торган әһәмиятле бер үзенчәлеге (акыл, күңел, талант һ.б.ш. тур.). *Төпле акыл дигән хәзинәне беркемгә дә кушучлап бирмиләр.* М.Хәсәнов. *Имтихан – һәрчак белем хәзинәсен тикшерү ләбаса!* М.Хуҗин. *Рәхмәт яугыры, кызның акылы хәзинә икән: очрашуны бакчаның иң түрендә, иң аулак җирендә тәгаенләгән.* М.Әмирханов

◊ **Хәзинәдә бары** Күпме бар, шуның кадәр, булган кадәре, бар кадәренчә. *Миллиардлаган кеше яшәгән Җир шарындагы караңгы бер татар авылының сукыр лампа янган кечкенә генә дүртпочмаклы өендә дүрт кешедән торган дәүләт, иртәгәге көн турында уйламыйча, хәзинәдә бары белән ашауэчүне дәвам итте.* Н.Әхмәдиев. *Аның садәлеген капламас өчендер, постау я эскәтер япмаганнар, хәзинәдә бары ялангач такта өстенә шул килеш кенә тезелгән.* К.Кәримов

**ХӘЗИНӘДАР** *и. гар.-фар.* Хәзинә тотучы, хәзинә хуҗасы; казначы. *Халкыбызның бәясе чикләнә алмаслык бай хәзинәсен җыюда Нәкый иң булдыклы хәзинәдар булып, ул хәзинәне искиткеч матур һәм кыйммәтле җәүһәрләр табып тагы да баетты һәм ул байлыкның иң ышанычлы сакчысы булды.* Б.Урманче. *Шуннан соң, Бәдретдин әфәнде Нәзиров хәзинәдар сайланып, җыелган акча аңа тапшырылды вә укытучыларга укыткан айлары өчен айга 35 шәр сум вазифа билгеләнде.* Р.Зарипов

**ХӘЗРӘТ** *и. гар.* 1) Мөселман дин әһелләре, руханилар, мулла-мөәззин һәм мәдрәсә укытучылары исемнәре янында килә торган хөрмәтләп мөрәҗәгать итү һәм атау сүзе. *– Аңладым мин сине, улым, – дип, яшьле күзләрен яшерергә азапланган малайны үзенә таба кысты Нуриәхмәт хәзрәт.* Р.Мөхәммәдиев. *Ирмәш хәзрәт, әлбәттә инде, Мөхәммәтгалине ихлас күңелдән сөенеп каршылады, мулдан бәреп чыккан күз яшьләрен яшерүне дә кирәк санамады.* В.Имамов

2) *сөйл.* Мулла, дин әһеле. *Бердәнбер кордашының вафаты Фәтхулла хәзрәтне аяктан ега.* А.Тимергалин. *Ит исе чыккан тәбәнәк өйгә килеп кергәч, хәзрәтнең күзе чыбылдык артындарак посып бәлеш майлап йөргән яшь киленгә төште.* М.Мәһдиев

3) Гомумән олылау, хөрмәтләү сүзе. *Менә шундый изгелекләре өчен Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәтләре аның малына, дәүләтенә бәрәкәт бирә, бәхете ачыла, ул елдан-ел байый гына бара иде.* Г.Ибраһимов. *Патша хәзрәтләре Габдессәлам мулланы кабул итә.* Р.Батулла

**ХӘЙЛӘ** *и. гар.* 1) Алдан уйлап куелган астыртын явыз ният, астыртын уй; нинди дә булса эштә мәкер, астыртынлык. *Кара әле, Шамил, болар, Тәскирә белән сүз куешып, хәйлә белән безне саварга план кормадылар микән?* Д.Салихов. *Аны хәйлә белән генә җиңеп булыр.* А.Гадел

2) Нинди дә булса максатка ирешү өчен уйлап чыгарылган ялган сылтау, сәбәп, эмәл. *Хәйләгә осталар югары дәрәҗә ала, майлы калҗаның дәве аңа эләгә.* А.Гыйләҗев. *Бу юлы инде, ниһаять, Фәләх тә хәйләсен тапты: – Кызганычка каршы, без дүртәү идек шул, Гасимә ханым, – диде ул, котылам, ахрысы, бу бәйләнчектән, дип сөенеп.* В.Нуруллин

3) Берәр нәрсәгә нигез, сәбәп булырлык, нәрсә өчен булса да акланырлык очрак, хәл. *Безнең әни, алдау-йолдау белән хәйләнең нәрсә икәнен белмичә,*

*һәммәсен турыдан-туры ярып салучы чамасыз да беркатлы кеше иде.* Г.Бәширов. *Көтмәгәндә каушап калуын сиздермәс өчен, ул хәйлә тапты.* З.Мурсиев

4) Тапкырлык, зирәклек, осталык, уйлап табучанлык. *Кеше үзенең акылы, хәйләсе, чаялыгы, стихиядән акыллылыгы буенча өстенлеге белән җиңеп чыксын иде – безнең шуны күрәсебез килә.* М.Җәлил. *Татар булгач, хәйлә, акыл ягы да капчык-капчык инде аның.* Н.Әхмәдиев

5) Нәрсә дә булса эшләү, берәр нәрсәне хәл итү өчен юл, ысул, чара. *Зирәк халыклар бит алар, моның да берәр хәйләсен тапмаслармы?* Г.Толымбай. *Алай-болай шикләнеп ачмасыннар өчен, кечкенә генә хәйләсен дә тапты: ике якка ачылмалы открытка уртасына бик пөхтәләп, үтүкләп «яшереп» куйды.* А.Әхмәтгалиева

6) Хикмәт, асыл, сер, җай. *Җир казуы таныш миңа, Беләм аның хәйләсен.* Н.Әхмәдиев. *Үзе оста булган кеше яхшы белә: һәр эшнең үз җае, үз хәйләсе була.* З.Зәйнуллин

7) *күч.* Кемгә дә булса зарар китерү өчен алдан уйланылган мәкерле гамәл; тозак. *Бу кешегә хәйлә-тозаклар күп, бик күп кирәк булачак, югыйсә ул әлеге максатына шуларсыз үлсә дә ирешә алмаячак!* З.Хөснияр

◊ **Хәйлә базы** *к.* **хәйлә капчыгы**. *Куяннарны, керпене, Хәйлә базы төлкене Инде җитәрлек куган.* Н.Әхмәдиев. **Хәйлә капчыгы** 1) Бик хәйләкәр, еш алдый торган кеше. *Соңыннан мәгълүм булганча, ул хәйлә капчыгы Казаннан кайткан саен: «Менә Сәләхдин төяп җибәрде әле, сата торырга кушты, үзе күбрәк тә алып кайтыр әле...» – дип сайраган.* К.Миңлебаев. *Ике ахирәт, кышкы озын төннәрдә кичләр утырганда, шул малайны телләреннән төшермиләр иде: үзе шук, үзе шаян, үзе сөйкемле, үзе хәйлә капчыгы булды шул.* К.Кара; 2) Башкалардан яшерен сер саклана торган урын, сер капчыгы. *Ул да хәйлә капчыгын кысып бәйләде: – Әй, бармасам да ярый әле.* Н.Гыйматдинова. *Хәйлә капчыгы буш булмаган, димәк.* Р.Мулланурова. **Хәйлә кору** Берәр максат белән нинди дә булса мәкерле юллар табу, астыртын эш планлаштыру, кемгә дә булса тозак кору. *Бачманның ниндидер тозак – хәйлә корырга чамалавын һәммәсе дә аңлый, ләкин хатынкыз киеменә төренү яугирләрнең минминлеген ашый, гарьләндерә иде.* В.Имамов. *Нәрсә дә булса уйларга, берәр хәйлә корырга кирәк.* А.Гадел

**ХӘЙЛӘКӘР** *с. гар.-фар.* **1.** 1) Хәйләле юллар белән эш итә торган. *Утта янмый, суда батмый торган, юха еландай хәйләкәр сәүдәгәр Садакны Харәзем шаһы Олуг Мөхәммәт, илчесе итеп, Төрки Болгарына җибәрә.* М.Хәбибуллин. *Акчасын да түләгән иде югыйсә, сатучысы да бит аның хәйләкәр нәмәрсә: әйтеп-нитеп тормаган.* М.Галиев

2) Тапкыр, зирәк, оста, беркайчан да югалып калмый торган; теләсә нинди хәлдән чыгу юлын, чарасын таба торган. *Әрсез, хәйләкәр булмасаң, батасың бу заманда.* И.Юзеев. *Бернинди каршылык алдында да тукталып калмый торган, кыю, батыр, хәйләкәр, акыллы, гади солдат турында аталарча хәстәрлек күрүче адәм, диләр аны.* З.Мурсиев

3) Хәйлә, мәкер, астыртынлык һ.б.ш.ны чагылдырган (тавыш, караш, елмаю һ.б. тур.). *Әниемнең апасы, әтиемнең җилкәсенә таянып, хәйләкәр тавыш белән: – Ул алай дип әйтмәде. Син үзең: «Динара минеке түгел», – дидең, бар, кереп гафу үтен хәзер үк хатыныңнан! – дип өндәде.* Э.Шәрифуллина. *Хәйләкәр күзле, кешеләргә сөзеп һәм сынап карый торган администратор күпне күргән, шактый гына еллар төрмәләрдә баланда ашаган кеше иде.* Мәйдан // Шаянлык, серлелек, хәйлә, чагыла торган. *Сибгат аганың күзләрендә хәйләкәр елмаю кабына.* М.Шабаев. *Хәсән, хәйләкәр елмаюын яшерергә тырышып, түбәтәе белән йөзен сыпырып алды.* А.Әхмәтгалиева

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Хәйлә белән; астыртын, яшерен, эшнең асылын белгертмичә. *Күп очракта һөҗүмне дошманга караганда остарак һәм хәйләкәррәк башкарып чыгабыз, тиешле биеклектә ныгып калабыз.* Г.Гомәр. *Бу мәсьәләдә авызы бер тапкыр пешкән Самат хәйләкәр эш итте.* Г.Галиева

2) Серле итеп, нәрсәнедер әйтеп бетермәү яисә астыртынлык төсмере белән (елмаю, карау һ.б.ш. тур.). *Рәфис, күзен хәйләкәр кысып, Айрат Бәдретдиновичка карап алды.* А.Вергазов. *Өстәл башында тирләп-пешеп аш эчеп утырган әти миңа хәйләкәр генә күз кыса: эләктеме, янәсе.* Д.Булатова // Мутлык, уенчаклык белән. *– Син дә кунак, мин дә кунак, атка печән кем сала, дигәндәй, бөтен кеше дә шәһәргә китеп бетсә, авыл сәхнәсендә кем уйнар? – диде ул, хәйләкәр көлемсерәп.* Д.Булатова

**3.** *и. мәгъ.* Үзенең максатына ирешү өчен хәйләләр белән эш итүче кеше; хәйләгә оста кеше. *Күпме ахири күршеләр булып яшәп тә, мондый хуш исле тәмле ипине өстәленә куйганы булмады хәйләкәрнең.* Н.Сәйяр. *– Дөнья хәйләкәрләр, комсызлар һәм мәкер ияләре кулында, – дигән казый Яхъя.* Ф.Яхин

◊ **Хәйләкәр таз** Беркайчан да югалып калмый, барлык киртәләрне дә хәйлә белән җиңеп чыга торган үтә чая, тапкыр һәм зирәк кеше. *Нәрсә-нәрсә утыртылмаган, күзгә тәрәп ялганлый, хәйләкәр таз.* А.Алиш. *Хәйләкәр таз, кем белән ничек эшләргә, кем белән ничек яшәргә белә, безгә болай да ярар дип уйлый бугай.* И.Нәбиуллина. **Хәйләкәр төлке** Хәйләгә бай, астыртын, оста хәйләле торган кеше. *Хәйләкәр төлке, өстәвенә әле ачуланган була тагын.* Г.Галиева. *Ул, хәйләкәр төлке, моның барысын да алдан уйлап эшләгән икән.* В.Нуруллин

**ХӘЙЛӘКӘРЛӘНҮ** *ф.* Хәйләкәр кешегә әверелү, хәйләләргә остару, төрле хәйләләр куллану. *Югыйсә мине ничек хәйләкәрләнергә берәү дә өйрәтеп куймаган.* Т.Миңнуллин. *Бер-берсенең генә түгел, үзләре алдында да хәйләкәрләнделәр алар.* А.Нәҗми

**Хәйләкәрләнә бару** Вакыт үткән саен тагын да ныграк хәйләкәрләнү. *Яшьләр елдан-ел остара, хәйләкәрләнә бара.* Идел

**Хәйләкәрләнә башлау** Хәйләкәрләнү билгеләре сизелү. *– Нигә алай хәйләкәрләнә башладың соң әле син? – дип канәгатьсезлеген белдерде апасы.* Р.Вәлиева

**Хәйләкәрләнә төшү** Бераз хәйләкәрләнү, тагын да хәйләкәрләнү

**Хәйләкәрләнеп алу** Аз гына хәйләкәрләнү. *Аю – елның һәр көне балдай татлы, бүре мул ризыклы булуын теләгәндә, төлке, бераз гына хәйләкәрләнеп алу да комачауламас, дип искәртте.* Якты юл

**Хәйләкәрләнеп бетү** Тәмам хәйләкәрләнү. *Кайберләре госпитальдән – алгы сызыкка, ә алгы сызыктан госпитальгә әләгә-әләгә тәмам хәйләкәрләнеп беткән, үзен күбрәк кайгырту ягын карый.* Х.Камалов

**Хәйләкәрләнеп тору** Әлеге вакытта, хәзер хәйләкәрләнү. *Хәйләкәрләнеп торма безнең янда, бөтен хәйләләреңне белеп бетердек бит инде.* Сөембикә

**ХӘЙЛӘКӘРЛЕК** *и.* Хәйләкәр булу сыйфаты; төрле хәйләләргә оста булу. *Ул үзендә өлгерлек, кыюлык, хәтта*

*бераз хәйләкәрлек, әрсезлек сыйфатларын да ачты.* Д.Каюмова. *Әйтерсең икесе дә фашизмны хәйләкәрлек белән дә җиңәргә куша.* Р.Рахман

**ХӘЙЛӘЛӘ́Ү** *ф.* 1) Мәкер һәм хәйлә белән берәр нәрсә эшләү; нәрсәне дә булса яшереп, бутап яки алдап, башкаларда ялгыш фикер тудыру, астыртын эш итү. *Ул һаман ничек тә булса хәйләләргә, астыртынлык белән алдырырга маташа.* З.Хәким

2) Үз максатына ирешү өчен, нинди дә булса сылтау, сәбәп табу, хәйлә белән эш итү; алдашу, юмалау. *Киресенчә, Карачурага кайтырга хәйләләп кенә чирлегә сабышып маташмыймы бу хатын, дип уйлый иде ул ара-тирә.* А.Гыйләҗев. *Гөлчирә Хәмитне сабый бала кебек хәйләли-хәйләли күлмәкыштаннарын салдырып, чиста кием кидертеп урынга яткырды.* Д.Каюмова // Дөреслекне башкаларга белгертмәү, әйтеп бетермәү өчен берәр ялган сәбәп табу, ялганлау. *– Юк, яңа больница салырга акча җибәргәннәрдер әле, – дип хәйләләде Гөлшаһидә.* Г.Әпсәләмов. *Тегесе дөресен әйтергә курыкты, чөнки карак тотылмаган бит әле, шуңа күрә хәйләләргә булды: – Кичтән хатын сырхап калган ие, тиз генә шуның хәлен белеп килим, дигән ием.* З.Хөсрияр

3) *сөйл.* Нинди дә булса эштә тапкырлык, зирәклек, креативлык күрсәтү. *Сөйләп бирә энесе Эчендә бар булганын. Ничегрәк хәйләләп, Нуждадан котылганын.* Р.Вәлиева. *Куркак икәнеңне күреп, Балаларың ояла. Үрнәк булып тор аларга – Беркайчан салма зыян. Хәйләләп ку явызларны, Син бит акыллы... Куян.* Ф.Тарханова

**Хәйләләп алу** Бер тапкыр хәйләләү. *Әллә соң Микулайның теге көнне ляякыл исерек кайтуын файдаланып, хәйләләп алыргамы?* Ә.Салах

**Хәйләләп җибәрү** Бераз, берникадәр хәйләләү. *Аның безне кабул итүе дә күңелне күрү, сыйпап һәм хәйләләп җибәрү өчен генә иде.* М.Вәлиев

**Хәйләләп йөрү** Һәрвакыт, даими хәйләләү. *Безнең урамнардагы чегәннәр, «без үзбәк-таҗик» диеп алдалап-йолдалап, хәйләләп йөрүчеләр Америкада сорана алмый, андыйлар әрәмтамак саналачак.* Р.Батулла. *Халыкның төрлесе бар: әнә Мирхәйдәровның хатыны эшләми, хәйләләп йөри диярләр, дип уйладым.* З.Мурсиев

**Хәйләләп карау** Булу-булмавын сынар өчен хәйләләү; хәйләләргә тырышу. *Искәндәр хәйләләп карарга булды.* Ф.Яруллин. *Хәйләләп кара инде, Зыятдин!* З.Хәким

**Хәйләләп куюу** Аз гына яки бер тапкыр хәйләләү. *– Калган акылы чыгып очмасын дип, богаулап куйган ул аны, сез нәрсә, белмисезмени?! – дип, уенынчынын бер итеп хәйләләп куя берсе, Килмешәк башындагы «чүлмәкне» беркадәр тарткалап караганнан соң.* К.Җәмит

**Хәйләләп яту** *сөйл.* Әле, хәзерге вакытта хәйләләү; шактый вакыттан бирле хәйләләү. *Ләкин уйлап табарга Миңа ирек бирмиләр, Өстәвенә тиргиләр: – Юкка баш ватма! – диләр, – Хәйләләп ятма! – диләр, – Синнән уйлап табучы Чыкмас, – диләр.* Р.Миңнуллин

**Хәйләли башлау** Хәйләләргә тотыну. *Гайшә хәйләли башлый: – Башым авыртты, – ди.* Р.Батулла. *Үлемне алдыйм, дип уйлап йөрсәң, ул үзе хәйләли башлый.* Г.Гыйльманов

**Хәйләли тору** Гел, даими хәйләләү. *Хәйләли торгач, тәки бераз акча төшерә бит кызый.* Р.Батулла

**ХӘЙЛӘЛӘШҮ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **хәйләләү** (1 мәгъ). *Алай берегездән берегез уздыра-уздыра ялганлагач, сезнең хәйләләшкәнне әллә кайдан сизгәннәрдер инде алар.* Идел

2) Берәр хәйлә табып ялганлау, алдау, дөресен әйтмәү; теләгәнен эшләү өчен берәр сәбәп, сылтау табу. *Вакыт үтсен дип кенә йөрмиләр, монда – эшли торган халык, хәйләләшми, кара тирләрен агызып, җан-фәрман эшли торган татарлар.* К.Кара. *– Юк инде, бу юлы хәйләләшә алмассың, берninди Бүредә дә булмадың син, – дигән Төлке.* Г.Гыйльманов

**Хәйләләшә башлау** Хәйләләшергә тотыну. *Шул көннән балабыз хәйләләшә башлады: берәр теләгенә каршы төшсәк, әлеге номерга шалтыратам, дип яный.* Кызыл таң

**Хәйләләшеп алу** Бер тапкыр яки аз гына хәйләләшү

**Хәйләләшеп карау** Тикшерү-белү максаты белән хәйләләшү. *Тик апалар, абыйлар Чүлмәк вата алмыйлар: Хәйләләшеп карыйлар, Хәрәмләшеп карыйлар, Чүлмәкнең кайдалыгын Белергә тырышалар, Күрергә тырышалар.* Р.Миңнуллин

**Хәйләләшеп тору** Хәзерге моментта хәйләләшү, һәрвакыт хәйләләшү. *Шул рәвешчә Балыкчы илә Чабак алдашып, хәйләләшеп торганда, бер күпне күргән Карт балык Чабакка бу сүзләрне әйтә иде: – И юләр Чабак! Син ни өчен һаман кармаклар тирәсендә әйләнәсең?* Г.Тукай

**ХӘЙЛӘЛЕ** *с.* **1.** 1) Мәкерле, астыртын, хәйләгә нигезләнгән, алдаулы. *Янәшәдә – һәммәсен үзара чәкәләштереп, хәйләле сәясәт йөртеп, мәңгелек Арыслан – Кытай иле җәйрәп ята...* В.Имамов. *Ул аларны хезмәт хакы түләми генә ун еллап үзенә эшләтте, фермадагы мал-туарны, төрле хәйләле юллар белән, шәһәрләрдәге ит кибетләренә озатып бетерде.* Ф.Яхин

2) *к.* **хәйләкәр 1.** (*3 мәгъ.*). *Тик сул флангта баскан тәбәнәк буйлы, йомры гәүдәле бер сугышчының йөзендә генә хәйләле елмаю чагыла, кысык күзләре ялтырый, яңаклары, яшүсмерләрнеке шикелле, ут янып тора.* Г.Әпсәләмов. *Әнә хәйләле күзләре ничек уйнаклый.* М.Әмирханов

**2.** *рәв. мәгъ.* Нәрсәнедер әйтеп бетермичә, нindидер яшерен мәгълүмат, сер белгән кебек; наянлык, мутлык белән, серле итеп. *Хатын, хәйләле көлемсерәп, аңа карап тора иде.* А.Вергазов. *Әни кеше: – Бәпкәм, эшең авыр түгелме? Иптәшләрең ару кешеләрме? – дип сораша башласа да, уен-көлке белән котылу җаен таба: – Әнкәй, кояш булып эшлим бит мин, – дип хәйләле елмайган була.* Р.Мулланурова

**ХӘЙЛӘСЕЗ** *с.* **1.** 1) Бернинди хәйлә, мәкер, алдау булмаган (сүз, эш һ.б.). *Бер җепкә тезелеп барган энҗе бөртекләре кебек саф, хәйләсез сүзләре Хәлимнең күңелендәге бозларны эретерлек иде.* Ф.Яхин

2) Саф, эчкерсез (кеше тур.). *Балыклары хәйләсез – кармакка тиз килеп каба, җылы суы иркәли, яшел урманы җиләк белән сыйлый.* Т.Әйди. *Йомшак сөйләп катыга утыртмый, ул риясыз, хәйләсез.* Н.Гыйматдинова

**2.** *рәв. мәгъ.* Мәкер, алдау, ялган катнаштырмыйча; мәкерсез генә. *Ләкин без моңа кадәр хәйләсез сугышкан идек, күзгә-күз килеп, без көчле идек, орышларда остарак идек, һәрчак өстен чыктык.* М.Хәбибуллин. *Шунлыктан хәйләсез эш йөртү мөмкин түгел, бигрәк тә сүздә, серләр биштәрен сүтәргә теләгәндә!* Ф.Яхин

**ХӘЙРАН** *с. гар.* **1.** 1) Гаҗәеп, искитәрлек, гаҗәпләнерлек. *Бу хәйран тамашаны күрер өчен, башка цехлардан да киләләр иде.* М.Хәсәнов. *Бары тик анда-санда кечкенә авыллар һәм әллә нигә бер очраган ныгытылган кальга-*

*шәһәрчекләр генә бу хәйран дөньяның буш түгеллеген, ә кеше яшәвен белгертә иде.* З.Мурсиев

2) Гаҗәпләнү, соклану яки аптырау чагылган. *Тәү кешедәй, хәйран күз белән карыйм бу зәңгәр кичкә ---.* Ш.Мәхмүдов. *Кузов рәшәткәләре аркылы тирә-ягына хәйран күз белән карыйкарый барган Муса уйга батты: менә нинди икән ул Алман иле.* Ш.Маннур // Аптыраган, гаҗәпләнгән. *Шаһи шунда Сыңар күзнең сүзен бүлеп, Бераз гына хәйран хәлдә торды көлеп, Сөйләргә башлады үз карарларын, Утырган соң ун минутлар башын бөгеп.* З.Бәшири

3) Соклангыч; әйбәт, бик яхшы. *Шушы кырыс дөньялардан башка Бар иде бит бер ил – хәйран ил!* Р.Бикбаев

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Бик, гаять, искиткеч. *Хәйран чибәр үзе, елмайганда көмеш тешләре балкып китте.* Г.Гомәр. *Башта хәйран тиз шуышты ул.* В.Нуруллин

2) Бик каты, бик нык, бик күп, бик озак, шактый һ.б.ш. мәгънәләрдә, нәрсәнең дә булса искиткеч күп һ.б. булуын белдерә. *– Әйбәт булыр иде, озак юлдан хәйран арылган, – дип, Маһирә риза булды.* Г.Галиева. *Бибинур әбинең бакый дөньяга күчеп киткәненә дә хәйран вакыт, диләр инде.* А.Фәләх

**3.** *хәб. функ.* Шаккату, гаҗәпләнү, таң калу, аптырау хәлендә булу турында. *Мин әле хәйран һаман да, белмәдем ни булганын.* Г.Тукай. *Бу эшләргә ул да хәйран иде.* Г.Минский

◊ **Хәйран булу** *к.* **хәйран(га) калу**. *Бу арада Биктимер, Фәрихә, яучы, Фатыйма кереп, кызның кочаклашып торганнарын күреп, хәйран булалар...* Г.Ильяси. *Бибиәсма, диләр, карчыклар, иркәм, дип аның аркасыннан кагалар, имеш, күргән егетләр аның йөзенә, зифа буена, аяк атлавына хәйран булып сөйлиләр.* Г.Ибраһимов. **Хәйран(га) калу** Ис китү, гаҗәпләнү, шаккату; аптырау; соклану. *Быел көз язганнарын укып чыкты, хәтеренә, кичергәннәренең муллыгына хәйран калдым!* А.Гыйләҗев. *Шул мизгелдә үк бердәм кабынган утлар яктысында Каюмны күрде дә Әмир хәйран калды.* В.Имамов. **Хәйран итү** Шаккатыру, сокландыру; аптырашка калдыру, гаҗәпләндерү. *Андагы бизәкләр дә, ук саплары да, ук башлары да, ук каурыйлары да күпне күргән мөсафирны хәйран итте.* Р.Батулла. *Соңгы ролең белән син һәммә кешене хәйран иткәнсең.* М.Маликова. **Хәйран калдыру** *к.* **хәйран итү**. *Ләкин Назимов шушы фикерен уртаклашырга дип Кимов янына барганда, Кимов аңа яңа хәбәр әйтеп хәйран калдырды.* Г.Әпсәләмов. *Бөтен авылны – бәлки әле бөтен районны булыр – хәйран калдырырга иде Әбүзәрнең исәбе.* А.Тимергалин

**ХӘЙРАНЛЫК** *и.* Хәйран булу хәле, аптырау, ис китү, шаккату халәте. *Килү белән исәнләшмәде, сәлам дә бирмәде, бер үләксәгә, бер Намаҗанга хәйранлык белән карады, җеп белән муенына аскан казанын карга куйды да үзе, хәлсезләнеп, шуңа утырды.* Г.Ибраһимов. *Кәримә аның бу сүзләренә бик тә гаҗәпләнде, шунда университет профессурасының күбесе ярым пеләш булуы, ә берсенең бөтенләй дә такыр икәнлеге исенә төшеп, һаман да хәйранлыкта калды.* Ф.Яхин

**ХӘЙРИЯ** *и. гар.* Җәмәгать оешмалары, дәүләт учреждениеләре яисә аерым затлар тарафыннан әдәбият, фән, сәнгать, дин үсеше өчен һәм мохтаҗларга күрсәтелә торган ярдәм, булышлык; иганә. *Тик хәйрия бит ул – үз кесәңнән үз табышыңны чыгарып бирү, 3 мең сум пенсия алган бабайның берәр балалар йортына 100 сум акчасын китерүе – менә кайда ул чын хәйриячелек.* Р.Вәлиев. *Бүген инде без милекле кешеләрнең хәйрия юлындагы гамәлләрен кире кагуның яки хосусый хәйриячелекнең әһәмиятен күрмәмешкә салынуның тарихи гаделсезлек чагылышы икәнен аңлыйбыз.* И.Шәрипов

**ХӘЙРИ́Я ИТҮ** *ф.* Матди ярдәм күрсәтү; билгеле гуманитар максатлар өчен акча бирү. *Соңрак «Кояш» газетында хәйрия ителгән акчаларның кая китүе турында һәм, фонд нигә эшли башламады, дигән сораулар белән мәкалә чыга, ләкин аннан соң матбугатта моның турында сүзләр күренми диярлек.* Идел

**ХӘЙРИ́Я КЫЛУ** *ф. к.* **хәйрия итү**. *Дәрдемәнд ярдәмгә мохтаҗ укытучылар һәм шәкертләргә хәйрия кылучы җәмгыятьнең рәисе вазифасын да башкара.* Л.Хәмидуллин. *Гимназия директоры Нурмөхәммәт Хөсәеновның үҗәтлеге аркасында алары да табыла килә: халкыбыз уяна, балаларга хәйрия кылырга теләүчеләр бер дә кимеми.* Кызыл таң

**ХӘЙРИЯЧЕ** *и.* Кемгә дә булса матди, акчалата ярдәм күрсәтүче кеше, иганәче. *Тарихыбызда менә шундый бармак белән санарлык хәйрияче һәм тагын да азрак сандагы меценатларыбыз арасында беренче бишлеккә керүчеләр исәбеннән бертуган Шакир һәм Закир Рәмиевләрне атарга кирәк.* М.Госманов

**ХӘЙРИЯЧЕЛЕК** *и.* Хәйрия эше белән шөгыльләнү күренеше; иганәчелек. *Билгеле, игелек кыл, мохтаҗларга ярдәм ит, дип кенә хәйриячелекне бүгенге байларның яшәү рәвешенә әйләндереп булмый.* Ф.Зариф. *Хәйриячелекне мин аң үсешенең күрсәткече дип уйлыйм.* Ватаным Татарстан

**ХӘКАРӘТ** *и. гар.* 1) Хурлау, кимсетү; мыскыл, хурлык. *Сибелде зур хәкарәт берлә хәтта башыма көлләр.* Г.Тукай. *Сатлык аркадашлар намусыннан Берни калмас – хәкарәттән башка.* Л.Янсуар

2) Ачу, нәфрәт. *Кунак сүзен бетерергә өлгермәде, Җәләлнең йөзе каралды, күзенә ачу чыгып, куллары калтырый башлады, һәм эченә сыя алмый ташып барган ачу вә хәкарәт берьюлы бәреп чыгарга якынлады.* Г.Ибраһимов. *Хәкарәт – сине баскан чир, Түбәнлек... мәңге китмәсме?* Р.Гаташ

**ХӘКАРӘ́Т ИТҮ** *ф.* Хурлау, мыскыл итү, кимсетү. *Улым киленемне шулай җәберләде, хәкарәт итте ки, рәхмәт Рәхиләгә, данлыбызны сатмады, минем белән бергә түзде, бергә чыдады.* А.Гыйләҗев. *Гаскәремне яуга алып китсәм, алар илемне хәкарәт итәчәкләр, диеп әйтә, ди.* Р.Зәйдулла

**ХӘКАРӘ́Т КЫЛУ** *ф. к.* **хәкарәт итү**. *Кешенең кешелеген изү, түбәнлеккә төшерү, хәкарәт кылу һәм аны мәсхәрә итү өчен, бу «тормыш»ны белмәгән ир затларның да (хатын-кызны әйткән дә юк) уена килә алмастай ысуллар куллану...* Р.Кәрами. *Каберлек – изге урын, кайсы халыкныкы һәм кемнеке генә булмасын, аны бозарга, чүпләргә, хәкарәт кылырга ярамый.* Ф.Яхин

**ХӘКАРӘТЛӘҮ** *ф.* Хурлау, кимсетү, мыскыллау. *Йогышсыз тәкъдимегез белән мине дә, үзегезне дә, басып торган җирегезне дә хәкарәтлисез.* А.Гыйләҗев. *Әлмисактан килгән Китап сүзен Хәкарәтләү – язык, харамдыр.* Г.Морат

**Хәкарәтләп бетерү** Бик нык хәкарәтләү

**Хәкарәтләп йөрү** Гел, һәрвакыт хәкарәтләү. *Танышларын хәкарәтләп йөрү*

**Хәкарәтләп тору** Хәзерге моментта яки һәрвакыт, даимән хәкарәтләү

**Хәкарәтли башлау** Хәкарәтләргә тотыну. *Бик ихтимал: хатын елый, профессорны хәкарәтли башлар.* А.Расих. *Бөтен гаммәви мәгълүмат чараларында*

*диярлек әлеге атаклы галимнәрне хәкарәтли башладылар.* Р.Зәйдулла

**ХӘКАРӘТЛЕ** *с.* **1.** Хурлый торган, мыскыллы, кимсетүле. *Госманның өстенә берсеннән-берсе авыр, хәкарәтле сүзләр яуды.* И.Салахов. *Шуннан соң шул ук егет, үзенә бик җитди кыяфәт биргән булып, Вәлигә әйләнде дә хәкарәтле җитди бер тавыш белән: – Сез кайсы мәдрәсә талибларыннан буласыз? – дип сорады.* Г.Рәхим

**2.** *рәв. мәгъ.* Хурлап, кимсетү катнаш мыскыллап. *Ул хәкарәтле елмаеп, хәкарәт вә дошманлык тулы күзләре белән Госманны сөзә иде.* Ф.Әмирхан. *Бер совхоз җыелышында район вәкиле сыйфатында катнашканым һәм шунда директорның әле бер, әле икенче белгеченә, урта буын җитәкчеләргә кадалып-бәйләнеп, кызарынып-бүртенеп аты-юлы белән хәкарәтле акырынулары истә калган.* З.Зарипов

**ХӘКИМ** *и. гар.* **1.** Гыйлемле, укымышлы кеше; белгеч, галим, хикмәт иясе. *Хаким кеше хәким дә булса икән!* Р.Фәйзуллин. *Килешә алмагач, болар гадел хәким янына барырга булганнар.* Р.Вәлиев

**2.** *с. мәгъ.* Укымышлы, гыйлемле, хикмәтле. *М.Кәримнең йөзләгән тәнкыйть, әдәби-публицистик язмаларын укыган кешеләр аны халкының хәким елъязмачысы итеп кабул итте.* Р.Фәйзуллин

**ХӘЛ** *и. гар.* 1) Кешенең физиологик һәм рухи халәте, үзен ничек хис итүе. *Соңга табарак, авыруның хәле яхшыра башлагач, Рәйханә апа аңа җайлап кына, әкренләп-әкренләп кенә бүтән төрле яңалыкларын да чишә башлады.* Н.Фәттах. *Сәйфулла йөгереп барып җиткәндә, Мәҗитнең хәле начар иде.* З.Зәйнуллин

2) Физик көч, егәрлек, куәт. *Рәсем ясалып беткәнче, арыганлык аның уена да кермәде, ә иң соңгы бияу салынуга, ул үзен көчсез хис итте, хәтта басып торырлык та хәле калмады.* Г.Кутуй. *Ары таба укырга хәле дә калмады, ихтыяры да җитмәде.* А.Хәлим

3) Матди мөмкинлек. – *Ике баласын да, анасын да туйдырырлык хәлем бар, – диде Әкрам.* Ф.Яруллин. *Югыйсә республиканың икътисади хәле күзгә күренеп күтәрелә иде соңгы елларда, күпләр өчен үрнәк булып тора иде.* Р.Мөхәммәдиев

4) Аерым кешенең җәмгыятьтә тоткан урыны, роле, социаль статусы, дәрәҗәсе. *Бер яктан, монда коллык хәлендәге халыкның бәйрәме күздә тотыла: эчтән генә, тышка чыгармыйча, чит-ятка белдермичә генә уздырыла торган бәйрәм...* М.Вәлиев. *Монда бит инде кешенең социаль хәле дә, кеременнәре дә исәпкә алына.* Р.Юныс

5) Эш һәм вакыйгалар барышында төрле сәбәпләр аркасында туган уңай яки тискәре шартлар; берәр эшнең барышы, торышы. *Әмма бернигә кысылмыйсыз, нәрсә бирәбез – шуңа риза буласыз, чөнки безнең үзебезнең дә хәлебез яхшы түгел...* Ф.Бәйрәмова. *Ә бит, чынлап карасаң, райондагы бик күп эшнең нинди хәлдә булуы нәкъ менә шушы кешеләрнең үзләреннән тора!* М.Вәлиев

6) Иҗтимагый-сәяси мөнәсәбәтләр, вакыйгалар һ.б.ш. тәшкил иткән вазгыять. *Икенчедән, дөнья хәлләре белән бөтенләй кызыксынмый, китап укымый, кино-театрларга йөрми, ягъни культурасыз.* В.Нуруллин. *«Әллә халыкара хәлләр начарланганмы?» – дип сорады Наилә.* А.Гыйләҗев

7) Тормыш шартлары, көнкүреш торышы; төрле вакыйгалар, яңалыклар. *Әйе, Хәбирне күрмичә, андагы хәлләрне сораштырмыйча, уллары турында белешмичә китү кунаклар өчен мәгънәсез бер эш булыр иде.* Н.Акмал. *Миннән аермалы буларак, дустым күңелендә ни бар – рәхәтләнеп сөйли, яза, өй хәлләрен дә, үзенең ни уйлавын да яшереп-нитеп маташмый.* А.Әхмәтгалиева

8) Нинди дә булса көтелмәгән, сирәк, сәер, кызыклы һ.б.ш. вакыйга, билгеле очрак. *«Бәйрәм» сүзе чыгу белән, иртәнге хәлне искә төшереп, өчесе дә берьюлы елмаешып алдылар.* Н.Фәттах. *Шуның өстенә тагын Фәләхнең эшендә дә күңелсез хәл килеп чыкты: гаражда эшләүче бер слесарьның «КамАЗ» кабинасыннан төшкәндә, егылып, аягы сынган иде.* В.Нуруллин

9) *физ.* Матдә кисәкчекләренең үзара тәэсир итешү, урнашу, хәрәкәт итүе һәм тыгызлыгы, температурасы үзгәрү белән бәйле күренеш, халәт. *Ә каучук цехында исә, моңарчы күп цехлар буйлап сыек хәлдә күчеп йөргән газ каты брикетларга әверелү сәбәпле, эш авырлаша.* Р.Хисмәтуллин. *Игътибар итик: эремә каты халәттә дә, сыек халәттә дә була ала, эретелмә һәм коелманы бары тик каты хәлдә генә күз алдына китереп була.* Фән һәм тел

◊ **Хәл алу** 1) Ял итеп алу, көч туплау. *Ул, бераз хәл алырга дип, түгәрәк алан кырыендагы бер имән төбенә барып утырды.* А.Вергазов. *Бераз хәл алырга дип кенә җиргә сузылганнар иде, тиз арада онытылып та киттеләр.* З.Мифтахов; 2) Авыруы җиңеләеп китү, савыккан кебек булу. *Шулай дулкын агымын тыңлап комда бер 10–15 минут ятканмындыр, күз алларым караңгыланганы беткәндәй булды, ачык аң керде, бераз хәл алдым.* Г.Хөсәенов. *Чумак әфсенләгән суны эчеп кенә хәл алдым, дигәннәрен үземнең ишеткәнем бар.* М.Маликова; 3) Матди як яхшыру, рәтләнеп китү. *Соңгы елларда гына хәл алдылар бит әле алар.* Р.Вәлиев. **Хәлгә керү** Кемнең дә булса борчуын, кайгысын һ.б.ш. аңлау, кемгә дә булса ярдәмчел, игътибарлы булу, мөмкинлекләрен исәпкә алу. *Үзе болай хәлгә керә торган ипле кеше ул.* В.Нуруллин. *Аз гына да хәлгә кермәсләр микәнни, аның гаебе белән түгел ич, өстәвенә, беренче тапкыр булгач, уздырып җибәрмәсләрме икәнни соң?* Г.Бәйрәмова. **Хәл(дә) барынча** *к.* **хәлдән килгәнчә**. *Өй котлап, менә мин дә сиңа хәлдә барынча әз-мәз нәрсә китергән булдым, ди.* Г.Ибраһимов. *Белгән догаларын, Корьән аятьләрен укыды, кабернең өстен рәтләп, язлар җиткәч килгәндә табуы җиңел булсын диеп, туң җиргә хәле барынча казык та төртеп куйды...* А.Хәлим. **Хәлдән килгәнчә** Булдыра алганча, мөмкинлектән чыгып, көч җиткәнчә. *Мә кәгазь, хәзер үк гариза яз, хәлдән килгәнчә матди ярдәм дә күрсәтермен.* Г.Гомәр. *Хезмәтем матбугат, китап басу белән турыдан-туры бәйле булганга, үзебездә дөнья күргән әсәрләрне хәлдән килгәнчә укып барырга тырышам, кайбер шигырьләрне хәтта куен дәфтәренә дә күчереп куям.* Р.Фәйзуллин. **Хәлдән килү** Булдыра алу, булдыру, мөмкинлек булу. *Кер юу машинасы алырга кирәк тә бит, әлегә хәлдән килми.* М.Маликова. *Хәлдән килерме безнең бу саз-урманнар уртасында шулкадәр халыкны даими рәвештә кулда тоту?* И.Хуҗин. **Хәлдән таю** Хәлсезләнү, көчсезләнү, бик нык ару. --- *буш вакытларында ишегалдына килеп кергән кеше тавыгын яисә мәчесен хәлдән тайганчыга кадәр куып йөрү, я булмаса болай да санаулы гына тавыкларының җитмәгәнен эзләп йөрү ишеләр булып кына тора иде.* К.Җәмит. *Умарталык аланына җиткәндә тәмам хәлдән таелган иде инде.* Р.Мөхәммәдиев. **Хәле хәл** «Эшләре начар, мөшкел» мәгънәсендә. *Нәҗипнең хәле хәл*

*икәнне каян иснәнгән, диген...* А.Гыйләҗев. *Киресенчә, хәле хәл булуга карамастан, башында туган ниятен гамәлгә ашырырга ашыгуы сизелә.* С.Сабиров. **Хәл җыю** *к.* **хәл алу**. *Авыл тау астында күмелгәч, утырып хәл җыярга туры килде.* А.Тимергалин. *Хәл җыйгач, дигәне исәнлек-саулык ныгуга гына бәйле түгел, күбрәк матди як белән бәйле иде...* Л.Хәмидуллин. **Хәл кадәре(нчә)** *к.* **хәлдән килгәнчә**. *Чөнки мин үзем хәл кадәре бу хөкүмәтне урынлаштыру өчен көрәштем, корал белән чехларга каршы сугыштым.* И.Салахов. *Ләкин гел аһ орып утырып булмый, үземә эләккән билетка хәл кадәренчә җавап әзерләргә кирәк иде.* В.Нуруллин. **Хәл керү** 1) Бераз көч туплау, хәлләнү; арыганлык бетү. *Чатнап тамагың кипкән чакта, йотлыгып, бер стакан су эчеп җибәрсәң, аның сихәте шунда ук кан тамырларың буйлап бөтен тәнеңә тарала, шунда ук хәл керә, бөтенләй икенче кеше буласың да куясың.* А.Хәсәнов. *Беркавым шулай ятканнан соң, чак кына хәл кереп киткән төсле була, Алиханның башы яңадан эшли башлый.* З.Хөснияр; 2) Терелә, сәламәтләнә башлау. *Әкренләп Алига хәл керә. Шулай да тәмам аякка басар өчен, аны шифаханәгә салып дәваларга кирәк була.* И.Диндаров. **Хәлләр бар** «Хәбәрләр, вакыйгалар, вазгыять әйбәт түгел» мәгънәсендә. *Йортта хәлләр бар! Бөтен стояклар шытырдап каткан.* А.Гыйләҗев. *«Хәлләр бар икән монда» дигән уйдан башка уй килмәде Әгъләм башына.* Л.Лерон. **Хәл туплау** *к.* **хәл алу**. *Беравык хәл туплагач, --- якташының җансыз авыр гәүдәсен өскә – чокыр читенә чыгарып салды.* Г.Кашапов. **Хәл эчендә булу** 1) Бик каты авыру; үлем хәлендә булу. *Ә без әни әле исән чакта, әмма инде хәл эчендә яткан вакытта кайтып җиттек.* В.Нуруллин. *Берничә көннән дусты Нәҗия хәбәре аша больницага килгән әнисе кызының нинди бүлектә икәнен белүгә, бу юлы да кешечә булмавына эчтән сызланып куйса да, хәл эчендә яткан, агарынып калган кызын җәлләп, артык сорашмады.* Г.Бәйрәмова; 2) Ташландык хәлдә булу; бетү, юкка чыгу хәлендә булу. *Ә ничаклы авыллар хәл эчендә?!* А.Гыйләҗев. *Оренбург хәл эчендә. Моңа кадәр бирелгән ярдәм генә җитми.* Казан утлары. **Хәл юк** 1) «Мөмкин түгел», «булмый» мәгънәсендә чарасыз булу, мөмкинлек булмауны белдерә. *Әмма берни эшләр хәл юк, терсәкне тешләп булмый.* А.Тимергалин. *Кача-поса гына килгән, дөресрәге, бөтенләй өмет итмәгән сөенеч вакыйгаларны ашыктыра, тыелып калырлык хәл юк, буйсынырлык акыл, кире чигенерлек чара юк.* К.Кәримов; 2) Үзеннән алда килгән сүзләр белән бергә «ул очракта», «әгәр ... булса»; «әгәр ... итсә» мәгънәсендә. *Ишек ачып керер хәл юк: «Урамда йөргән аяк киемеңне ник өйгә сөйрисең?» – дип, әни тиргәнә башлый.* Л.Гыймадиева. *Әтисенең: «Сүз әйтер хәл юк, эттән алып эткә салырга гына тора», – диюен аңларлык яшьтә түгел иде әле кыз.* М.Яһудин

**ХӘЛӘЛ** *с. гар.* **1.** 1) Шәригать тарафыннан рөхсәт ителгән, дин ягыннан тыелмаган; *кирес*е: **харам**. *Җирдә туган сабыйларга, Яшьләргә һәм картларга Насыйп булсын гомер буе Хәләл ризык ашарга.* К.Булатова. *Әлбәттә, безнең шәһәрләрдә дә хәләл ит кибетләре, ашханәләре бар.* Р.Вәлиев

2) Үз көче, хезмәте белән, тыелган юлларга кермичә, намус белән табылган; намуслы. *Рәшит күп вакытын, хәләл малын дини оешмага, ярдәмгә мохтаҗ милләттәшләребезгә, татар җәмгыятенә биреп бара.* Д.Гыйсметдин. *Тик хәләл мал гына бәхет китерә ул, балам.* А.Мансуров

3) *сөйл.* Никахлы. *– Ю-у-ук, – дип аяк терәп карышкан булды Фәридә, – хәләл иреңне, газиз балаңның атасын ташлап, ничек чыгып китмәк кирәк?!* К.Кара. *Дулкыния хәзер Әнвәрнең кочагына ташланыр: «Әнвәр, минем гаебем юк бит, ышан!» – дип елар, Әнвәр исә: «Ничек хәләл хатыныма ышанмыйм ди инде, билгеле, ышанам, бу кемнеңдер игътибарсызлыгы аркасында килеп чыккан хәл» – дип, аны юатыр, тынычландырыр иде.* Г.Бәйрәмова

4) *куч.* Изге. *Баланың күңеле сукыр, диюләр рас шул: онытасыз сез аналарыгыз имезгән хәләл сөтне...* Т.Әйди. *Тугызар ай күкрәк астында күтәрү, хәләл сөтеңне ике яшькәчә имезү, чирләсәләр, керфек тә какмый үткәргән йокысыз төннәр...* Д.Булатова

**2.** *хәб. функ.* Лаек, тиеш, рөхсәт. *– Ул мал безгә хәләл, – диештеләр.* М.Галәү. *Тираннар канын кою безгә хәләл, бугазларыннан алыйк без аларның!* Р.Батулла

**3.** *и. мәгъ. к.* **хәләл җефет**. *Әмма шулар арасында иң чибәре – минем гомерлек хәләлем – Мәдинәм-гөлкәем.* А.Хәсәнов. *– Син кирәк монда, син, Нургалием, – дип, мөлдерәмә тулы күзләрен яшерергә тырышып, башын хәләленең күкрәгенә салды Газзәбану.* Г.Галиева

**ХӘЛӘЛ ҖЕФЕТ** *и.* Ир хатыны яки хатын ире, кемнең дә булса никахлы хатыны яки ире; җефет. *Хәер, минем гаиләмдә байлык өмет итеп алданган хәләл җефетем акча яратучы, малга табынучы зат булып чыкса, бергәбергә тату яши алмас идек.* К.Миңлебаев. *Ул Фәсәхов, ягъни мәсәлән минем хәләл җефетем, кырыкмаса кырык начальник белән дус.* Ф.Яруллин

**ХӘ́Л-ӘХВӘЛ** *җый. и.* Исәнлек-саулык; көнкүреш хәлләре. *Шуңа күрә, Таифәләргә күчеп киткәч тә, ул аларны чит итмәде, юл төшкәндә кагылып, хәл-әхвәл белешеп торды.* А.Гыйләҗев. *Сүз хәл-әхвәл белешүдән имтиханнар тирәсенә күчте.* М.Кәбиров

**ХӘЛБУ́КИ** *терк. төрек* Әмма, ләкин; шулай булуга карамастан. *Клара ихтыярсыздан: «Әллә тормаганнар инде», – дип уйлап алды, хәлбуки хуҗалар, кадерле кунакның йокысын кызганып, өй тирәсендә чуалмыйлар иде.* Ә.Еники. *Хәлбуки өстебездә түбә бар, җил-яңгыр тими, җан сакларлык кына булса да тәгаменнән дә аермыйлар.* М.Әмирханов

**ХӘЛВӘ** *и. гар.* Төелгән майлы орлыкларга яки чикләвек төшенә карамель кушып ясалган масса хәлендәге татлы ашамлык. *Тынлык, ниһаять, кунакларга яңа чәй, хәлвә, җимешләр китергәч кенә тарала башлады.* В.Имамов. *Ләйлә чәй әзерләгән арада, Алмаз машинасыннан бер кап хәлвә алып керә.* З.Хәким

**ХӘЛВӘФРҮШ** *и. гар.-фар. иск.* Хәлвә әзерләү һәм сату белән шөгыльләнүче кеше. *Аннан соң хәлвәфрүш нәфис киемнәр киеп, зәнбилгә хәлвә тутырып, урамнарда, базарларда сатып йөрер булды.* К.Насыйри. *Әгәр күз салган булсалар, анда качып кына «кәҗә сыйрагы» пыскытып яткан Әбүзәрне һәм аның җан дусты хәлвәфрүш Флүнне күргән булырлар иде.* А.Тимергалин

**ХӘЛВӘЧЕ** *и.* Хәлвә пешерү остасы. *Ширбәтчеләр янында сусынын басты, хәлвәчеләрнең татлы нигъмәтләреннән авыз итте, төрле илләрдән килгән базаркәннәрнең ят киемнәренә, аңлаешсыз телләрдә сөйләшүенә, аларның күплегенә, төрлелегенә хәйран калды.* Ф.Латыйфи. *Алырга теләүчеләр арасында «олы-кече, бай һәм фәкыйрь, хәлвәчеләр, икмәкчеләр».* Ф.Хуҗин

**ХӘЛДӘ** *бәйл.* Рәвештә, тәртиптә, килеш, кøенчә. *Ләкин болар, станциягә килеп җитүгә, машинаны кузгалып китеп барган хәлдә күрделәр.* Г.Рәхим. *Бер-берсенә сыенып утырган хәлдә, тегене-моны сөйләшеп, елга портына хәтле килеп җиттеләр.* Р.Кәрами

**ХӘ́ЛИТКЕЧ** *с.* Үтә әһәмиятле, бик мөһим; хәл итә торган, төп. *Көн бик җаваплы да, хәлиткеч тә булганга, Рәшит белән мин иртәнге алтынчы яртыда тордык.* З.Зәйнуллин. *Бу җаваплы, хәлиткеч очрашуга ныклап әзерләнде Зарифа.* К.Кара

**ХӘЛ ИТҮ** *ф.* 1) Нинди дә булса мәсьәләне, проблеманы чишү, җайлап җибәрү. *Республикада торак проблемасын хәл итүнең алдагы этабы торакны ипотека һәм озак вакытлы кредит бирү юлы белән сатып алуга бәйле булачак.* Р.Миңнуллин. *Ул шулай, абыйсы әйткәнчә, бөтен мәсьәләләрне дә җиңел генә хәл итсә икән.* Р.Камал

2) Мөһим карар кабул итү, бер фикергә килү. *Кемне кая эшкә җибәрү мәсьәләсе хәл ителә торган көн.* К.Миңлебаев. *Күпчелек тавыш белән хәл ителә: магнитофон тасмасын соңыннан Малютинга бирмәскә!* З.Зәйнуллин

3) *сөйл.* Билгеләү, ачыклык кертү; билгеле бер юнәлешкә борып җибәрү. *Мин үз язмышымны үзем хәл итәм!* И.Юзеев. *Югары уку йортында студентның язмышын тәүге сынау хәл итә.* Т.Галиуллин

**ХӘЛИФӘ** *и. гар. иск.* 1) Кемнеңдер урынын алган кеше, берәүнең вәкиле. *[Аллаһы Тәгалә фәрештәләргә] Адәм галәйһиссәламнең җир йөзенә хәлифә булуыннан хәбәр бирде.* К.Насыйри

2) *тар.* Мөхәммәд пәйгамбәрдән соң аның вәкиле буларак дин һәм дөнья эшләрендә бөтен мөселманнар өчен башлык, шул ук вакытта дәүләт белән идарә итүче зат; мөэминнәрнең әмире – мөселманнарда иң югары титул. *Кяфер мәмләкәтләр һәммәсе җыйналып, безнең хәлифәгә каршы сугыш белән килмәкче, ди.* М.Галәү. *Чит илдән килгән илчеләр хәлифә җибәргән ике кара байракны югары күтәрделәр, Алмыш ханның өстенә – кара чапан, башына ак чалма кидерделәр.* Н.Фәттах

**ХӘЛИФӘЛЕК** *и.* 1) Хәлифә булу, хәлифә дәрәҗәсе. *Хәзрәте Галидән соң хәлифәлек аның углы Хәсәнгә калды.* К.Насыйри. *Хәлифәлеккә иң эшлексез кешеләр утырып, алар, үзләренең тоткан зур урыннарыннан файдаланып, төрле истибдад һәм әшәкелек юлларына керделәр.* Г.Камал

2) *тар.* Башында хәлифә торган ислам дәүләте. *Кодрәтле хәлифәлекләр таралып, аларның төп халкы гарәпләр хәзерге вакытта ике дистәдән артык гарәп илендә гомер кичерә.* Х.Миңнегулов. *Чынаяктай ак тәнле, салам чәчле гүзәлләребез Рим сенаторларының сарайларын, соңрак, хәлифәлекләр барлыкка килгәч, хәлифәләрнең гаремнарын бизәгәннәр.* М.Хәбибуллин

3) Хәлифәне бөтен мөселманнарның да рухи хакиме дип карый торган дини-сәяси система. *Истанбул дәүләте, ислам хәлифәлеге һәркайда булган мөселманнар өчен мәгънәви бер сыену урыны, рухи таяныч, күңелләренә куәт, җаннарына юаныч, рәхәтлек иде.* Г.Баруди. *Төрек солтаннары үзләренең хәлифәлекләре Россия империясе мөселманнарына да тарала дип караган*

**ХӘЛИФӘТ** *и. гар. к.* **хәлифәлек** (*2 мәгъ.*). *Хәлифәттә 70 мең ялланган сугышчы хезмәт иткән, һәм хәлифә аларга елына ике миллион дирһәм түләп торырга мәҗбүр булган.* М.Хәбибуллин. *Бәркә хан ислам дине сагында нык тора, дин хакына, туганнан туганы Хулагу белән дошманлаша, чөнки христиан дине тарафдары Хулагу бөтен ислам дөньясына сугыш игълан итә, хәлифәтнең башкаласы Багдадны җимерә, мөселманнарны үтерә.* Ф.Бәйрәмова

**ХӘЛИФӘТЧЕ** *и.* Хәлифәтне кабат тергезү тарафдары булган кеше. *Иң кызыгы шунда ки: бу хәлифәтчеләр берәр җирдә «мөселманнарны кысалар», дип кычкырып кына алалар, шунда ук мөселманны чынлап эзәрлекләү башлана.* Безнең гәҗит

**ХӘ́Л КЫЛУ** *ф. к.* 1) **хәл итү** (*1 – 2 мәгъ.*). *Шулай, Мостафа, өч табак куеп эшләү тәкъдимегезне шушы ике-өч көн эчендә без директор белән икәү хәл кылырга булдык.* Г.Кутуй. *Ниһаять, егет хәл кыла: Розалия белән өйләнешергә әзер, үзенең соңгы карарын белдереп, шәһәргә соңгы хатын җибәрә.* К.Тимбикова. *Һәммәсен артык шау-шу куптармыйча гына хәл кылырга җай чыгып тора бит югыйсә.* М.Маликова

2) *сөйл.* Нәрсәне дә булса ашап, эчеп, кулланып, файдаланып бетерү. *Әйдә, улым, коймакны икәү хәл кылыйк.* Т.Галиуллин

3) *сөйл.* Эшләү, эш бетерү, шөгыльләнү. *Ни хәл кылып ятасың, катип Хафиз?* М.Хәбибуллин. *Ни хәл кыласың, ирләрдәге мең дә бер кимчелекнең иң тәүгесе шул була инде.* З.Мәхмүди

4) *күч.* Берәр гамәл кылу; берәр җитди адым ясау, нәрсә дә булса эшләү. *Яшәвем дә шул балам өчен генә минем, авырлы булмасам, күптән үзем белән бер-бер хәл кылган булыр идем, билләһи!* Г.Гыйльманов. *Үзегезгә бер-бер хәл кылып куярлар, дим.* З.Мурсиев

5) *күч.* Үтерү. *Иске танышлары Гөмбәне, заманында Шөрепне йөрткән, Мансурны «хәл кылган» өчен өстәмә түләү таләп итеп, Сакманов янында дәгъва белән йөргән Ренатны таныйлар.* Т.Галиуллин

**ХӘЛЛӘНҮ** *ф.* 1) Савыга башлау, авырганнан соң рәтләнү; хәл керү, көч керү. *Ашыйсы ризыгы бетмәсә, адәм баласы хәлләнә икән.* А.Хәсәнов. *Соңгы елларда гына бераз хәлләнде; әле дә дарухanә юлын таптый – алган радиациясе чыгып бетми.* Р.Кәрами

2) Авыр эштән яки ерак юлдан соң ял итеп хәл алу. *Тегендә Намаҗан йортындагы ашханәдә аш пешереп, аны кечкенә кисәк алабута икмәге белән ашап, азрак хәлләнгәч, ташчы Камали үзенең кыйналган күршесе балтачы Гәрәйне бу ашарга җыелган халык эченнән күзе белән эзләде.* Г.Ибраһимов. *Әз-мәз хәлләнгәч, Наилә күл тирәсенә атлады, кызуы сүрелә төшкән учакка карап торды, тая язып ярдан суга иелде, боткакка ябышып кулъяулыгын суга манчып, маңгаен чылатты, биек муенын юды, рәхәт булып китте.* А.Гыйләҗев

3) Үсеп килү, үсеп, үзен үзе карарлык, ата-анага ярдәм итәрлек хәлгә килү (бала тур.)

4) Матди яктан бераз яхшырак яши башлау; матди як рәтләнү, уңайлану; мохтаҗлыктан чыгу. *Мин монда каучук агачы плантацияләрендә эшләдем, азрак хәлләнгәч, йорт сатып алдым; тормышыбыз, Ходайга мең шөкер, түгәрәкләнде.* И.Хуҗин. *– Балам, менә бер өлешен биреп куйыйм әле, калганын азрак хәлләнгәч төшерермен, – дип, комендантка акча сузды.* М.Кәбиров

**Хәлләнә бару** Торган саен ныграк хәлләнү. *Мин дә тырышам, мин дә үрмәлим, һәм көннән-көн әкренләп хәлләнә баруымны үзем генә сизеп торам.* Ә.Еники

**Хәлләнә башлау** Хәлләнү билгеләре сизелү, күренү. *Калага җитәр алдыннан, Идел тугаенда, бу ахмак бабай, бер эш белән туктаган чакта, азрак хәлләнә башлаган улын җилкәсенә күтәреп-*

*ме, ничектер, агач арасына алып кереп китә башлаган.* Г.Ибраһимов. *Инде хәзер хәлләнә башлаган Шәрифә үзе Нуриханнан кача кебек.* Н.Гыйматдинова

**Хәлләнә төшү** Бераз хәлләнү. *Хәлләнә төшкәч, сыер алырбыз.* К.Тинчурин. *Карчыгы вафатыннан соң бик нык авырып, ун ел гомерен читтә – балалары янында үткәргән карт, хәзер инде бераз хәлләнә төшкәч, Хәсәнбайның элек-электән килгән иң зур бәйрәменә – Акбабайның туган көненә дип кайткан иде бит.* М.Кәбиров

**Хәлләнеп алу** Тиз арада хәлләнү, бераз хәлләнү. *Шулай да су кереп, бераз хәлләнеп алырга ярый ул.* З.Мурсиев. *Төшке аштан бераз хәлләнеп алганнан сон, бригадир Фатыйх, Гаип, Ризван кебек яшьләрне алга бастырып алып, печән чабуга керештеләр: «Аллага тапшырдык, малларга бәрәкәтле азык булсын!»* Р.Шәфигуллин

**Хәлләнеп җитү** Тулысынча хәлләнү. *Хәзер ул хәлләнеп җитте шикелле.* Х.Сарьян. *Бик баеп, хәлләнеп җитәләр болар.* Р.Батулла

**Хәлләнеп килү** Акрынлап хәлләнү, хәлләнүгә таба бару. *Зөлфиянең больницадан сукыр эчәгесен кистереп чыкканнан соң яңарак кына хәлләнеп килгән чагы.* С.Сабиров

**Хәлләнеп китү** Соңгы арада сизелерлек хәлләнү. *Кичәгенәк йокларга ятканда, ул тәмам айнып, хәлләнеп китү нияте белән яткан иде, ләкин бүген иртән ул үзен әз генә дә хәлләнгән итеп сизмәде, киресенчә, аңа ул тагын да ныграк начарланган шикелле тоелды.* Н.Фәттах. *«Бәләкәй кызым ут яна, сөт йотса, хәлләнеп китмәсме», – дигәч, Гөлчирәнең әнисе чүлмәк белән сөт тоттырып чыгарган иде үзенә.* А.Әхмәтгалиева

**ХӘЛЛЕ** *с.* **1.** 1) Хәле булган, көчле, куәтле. *Күнегелгән эш: таңда да кузгалган бар, ярты төндә дә, атлар гына хәлле булсын, алар чыдасын, без карышмыйбыз, безнең эшебез шул, яшәвебез шул.* А.Гыйләҗев. *Көчлерәк, хәллерәкләре, хатын-кызны, бала-чаганы читкә төртеп, тизрәк үзләре вагонга эләгү ягын карый.* Р.Мостафин

2) Җитеш, мул тормышлы; материаль ягы башкаларныкына караганда күпкә яхшы булган. *Хәллерәк яки зур гаиләләр «кара-каршы өй»дә торганнар.* Г.Рәхим. *Әти-әниләре шундый хәлле, дәрәҗәле кешеләр булгач, әлбәттә инде, Фәләхне бала чагында да, үсеп җиткәч тә авылда һичкем кыерсытмады.* В.Нуруллин // Бай. *Шуңа да монда хәлле кешеләрнең балалары гына укый.* А.Гыймадиев. *Гадәттә, хәлле кешеләр үзләренең баеп китүләре хакында сөйләргә яратмыйлар.* Д.Гыйсметдин

3) Төзек, әйбәт хәлдә булган; таза, җитеш тормышны белдереп, чагылдырып торган (хуҗалык, йорт, оешма һ.б.). *Бәхетенә, бөтенләй үк тай тибеп бетермәгән икән: хәллерәк хуҗалыклардагы элеккеге әшнәләре кайсы арыш, кайсы бодай, солы саламы бирергә вәгъдә итте.* Ә.Хәсәнов. *Без, унлап студент, бик зур итеп төзелгән хәлле йортта – фатирда торабыз.* М.Садыйков // Эшләре әйбәт бара торган. *Мин хәлле генә җиргә эшкә урнашам.* Н.Гыйматдинова

**2.** *и. мәгъ.* 1) Көчле, егәрле. *Булдыра алган хәллеләр, ахрысы, шуны күрмәс өчен, шушы урман тынычлыгына кереп урнашалар.* З.Кадыйрова. *Бүген инде сыер асраучылар юк диярлек – бик хәлләр, үҗәтләр генә мондый «батырлыкка» бара ала.* Ф.Гыймалтдинов

2) Башкаларга караганда җитешрәк тормышта яшәүче, матди мөмкинлекләре яхшырак кеше. *Җиргә сыланып аркылы-торкылы сынып яткан игенне хәллерәкләр чабарга маташалар.* Г.Бәширов. *Хәллене таласалар да, алар барыбер мантый алмады.* Р.Батулла

**3.** *рәв. мәгъ.* Яхшы, әйбәт, җитеш тормыш белән. *Бер уйласаң, аның икенче ягы да бар: шушы акча авылда калачак, авылдашлар хәллерәк яши башласа, авыл өчен начармыни?* М.Мәһдиев. *Мәрхүмәнең туганнан-туганының балалары авылда хәлле генә дөнья көтеп яшиләр – шуларның печәнлеге, шуларның чөгендерлеге инде хәзер бу ятим нигез.* З.Мифтахов

◊ **Хәлле хәленчә** Һәркем үз мөмкинлегенә карап. *Һәркем хәлле хәленчә: кем чанасында өч пот, дүртне алучылар да бар, ике белән калучылар да булды.* А.Гыйләҗев. *Шуның янына хәлле хәленчә куй суйды, аш-су ясады.* Н.Фәттах

**ХӘЛЛЕЛЕК** *и.* 1) Көчлелек, егәрлелек. *Хәллелеге эшләвеннән үк күренеп тора*

2) Җитеш, таза, мул тормышлы булу. *Хәллелеккә ирешүдә Нык эшли Гайни башы.* Ә.Давыдов. *Кунак бүлмәсенең каршы як диварында ул заманның затлылык, хәллелек билгесе – стенка тора.* Шәһри Казан

**ХӘЛСЕЗ** *с.* **1.** 1) Хәле булмаган, көче җитмәгән, егәрсез. *Адашып калган хәлсез чебине сырып алган дәү каргалар кебек, аны биш-алты хатын-кыз урап алган.* А.Гыйләҗев. *Хәлсез сабыен күкрәгенә кысып тоткан хәлдә карават читендә утырды да утырды.* А.Әхмәтгалиева

2) Хәле беткән, көчсез калган, хәлдән тайган. *Таяк шикелле нечкә һәм озын, әмма хәлсез аякларын бик сәер итеп дүрт якка тырпайткан да имгән булып маташа.* Г.Бәширов. *Кырлар буйлап барганда, ябык, хәлсез куллары белән ишек тоткасына чытырдатып ябышып, ян тәрәзә аша тирә-юньне әсәрләнеп күзәтеп барды.* А.Вергазов // Хәле булмавын күрсәтеп торган. *Фатыйма бикә аның хәлсез йөзенә тагы бер мәртәбә кызганып күз салды да: – Ай-һай, балам, Зыя... Бигрәк беткәнсең икән... Артык өзлекмәсәң ярар иде, – диде.* Г.Ибраһимов. *– Хәтерләсәң шул, – диде хәлсез тавышы белән әнисе.* А.Мансуров

3) Хәерче, матди яктан начар тормышлы, ярлы. *Минә шул агай торып басты да әйтә миңа: – Син, Булат энем, – ди, – кешеләрне алай хәллегә дә, хәлсезгә дә аерып карама.* В.Нуруллин. *Минә минем булачак ирем булдыксыз, хәлсез, акчасыз булса, сезгә ошармы?* З.Хәким

**2.** *рәв. мәгъ.* Хәле булмаган килеш; көчкә-көчкә. *– Кирәкми... – дип, хәлсез пышылдады кыз.* Г.Әдһәм. *Мин үзалдыма хәлсез генә елмаерга маташкан арада, табиб әниемә сәер, юк-юк, сәер түгел, серле караш ташлады.* А.Әхмәтгалиева

**3.** *и. мәгъ.* 1) Көче, хәле булмаган кеше. *Карчык-корчык хасталар, җир иснәп сихәтләнергә чыккан хәлсезләр, яулык читен бөгеп күз яшьләрен сөрткән арада, елгыррак кызлар, малайлар буразналарга тәгәрәгән кукәйләрне эләктереп калырга ашыгалар.* А.Гыйләҗев. *Хәлле хәлсезне төрткәли, бай ярлыны этә, хезмәт кешесе, эшләп-эшләп тә, эшләгәненең әҗерен күрми.* Ф.Бәйрәмова

2) Ихтыярсыз кеше. *Хәлсезләр, кыюсызлар башта читтә торып торыр, алар күрәшнең безнең файдага икәнен күргәч кенә хәрәкәткә кушылырлар.* Г.Әпсәләмов. *Син шуны ятлап кал, Андрей кенәз: рус халкы гомер буе мескен һәм хәлсезләрне түгел, ә бәлки тимер куллы, мәрхәмәтсез җанлы хакимнәрне генә фәрештәдәй күрә.* В.Имамов

3) Ярлы кеше. *Инде байлар колхоздан качып киткән, безнең ише хәлсезләр*

*генә калган, дип сөйлиләр.* М.Маликова. *Бөтенләй хәлсезләре баеракларга имана җирләрен арендага биреп торганнар (бусы ачлык булмаган елларда кабатланып торган).* Яңа тормыш

**ХӘЛСЕЗЛӘНҮ** *ф.* 1) Хәл бетү, хәл китү, йончу, йөдәү, көчсезләнү, ару, хәлдән таю. *Бүген автобуста кайтып барганда, ул кинәт хәлсезләнде, агарынды.* З.Мәхмүди. *Ул шактый хәлсезләнгән, күтәреп төшергәндә, тәнен җыя алмыйча, Сәүбәннең куенына мәлҗерәп керде дә бетте.* Г.Гыйльманов

2) Ярлылану, бөлгенлеккә, мохтаҗлыкка төшү, матди хәле начарлану. *Сугыш вакытында хәлсезләнгән хуҗалыкны җитәкләү, ай-һай, җиңел түгелдер.* Т.Гарипова. *Ачлык-ялангачлык, атлар һәм авыл хуҗалыгы корылмалары җитешмәү хәлсезләнгән авыллардагы яшәешне тагын да катлауландыра.* Кызыл таң

**Хәлсезләнә бару** Торган саен хәлсезләнү. *Көннән-көнгә хәлсезләнә барган хатынның җанын әллә нинди авыр уйлар кимерә иде бугай.* М.Кәбиров. *Шуңа да аяклары да, куллары да хәлсезләнә бара.* А.Мансуров

**Хәлсезләнә башлау** Хәлсезләнүгә табан бару. *Нәкъ Тукай врачлардан шаяртып көлгәнчә, рас килеп чыкты: әлегә тикле азмы-күпме ярыйсы гына кыймылдаган Әсмабану абыстай, табибка күренгәннән соң, тыны бетүдән ешрак зарлана, хәлсезләнә башлады.* С.Сабиров. *Атна-ун көн эссе тузан арасында эшләгәч, егетләрнең кайберләре күзгә күренеп хәлсезләнә башлады, каты авырып китеп, эшкә чыга алмаучылар да бар иде.* Ф.Бәйрәмова

**Хәлсезләнә төшү** Бераз хәлсезләнү; тагын да ныграк хәлсезләнү. *Татар әдәбиятының болай да шактый сирәк булган яшь прозаиклар сафы алардан соң тагын да бирешә, хәлсезләнә төште.* М.Вәлиев. *Ялкын сүрелә-хәлсезләнә төшкәч, мин чыбыклар өстим.* Р.Фәйзуллин

**Хәлсезләнеп бетү** Тәмам хәлсезләнү. *Тоткыннар тәмам хәлсезләнеп бетә.* Р.Мостафин. *Хәлсезләнеп беткән Әхмәтсафа, урындыктан очып, стенага барып сыланды.* Ф.Сафин

**Хәлсезләнеп йөрү** Шактый озак вакыт хәлсез булу; һәрвакыт, гел хәлсезләнү. *Өч көн хәлсезләнеп йөргән идем, грипп килә, ахрысы.* Ф.Садриев. *«Җан югалту» дигән төшенчә дә бар: кеше көтелмәгән яки кискен психологик яра алса, яки ниндидер олы кайгыны тулаем кичереп бетермәгән булса, бөтен энергиясе шул ситуациядә, шул вакыт аралыгында калып, ул хәлсезләнеп йөрергә мөмкин.* Кызыл таң

**Хәлсезләнеп калу** Берәр хәлдән, тәэсирдән соң хәлсезләнү. *Яраланып госпитальдә ятулар, өйгә кайткач та юньлерәтле эш күрмәү сәбәпле хәлсезләнеп калган кулы, салам белән тарткалаша торгач, тиз арыды.* Н.Әхмәдиев. *Ләкин Җаббаров белән кыршылып беткән таныш баскычлар буйлап өскә күтәрелгәндә, аның бу тырышлыгы юкка чыгып, җанына чиркандыргыч куркаклык үрмәләп үтте, ул бөтен тәненең тыелгысыз дерелдәвен, аяк буыннарының хәлсезләнеп калуын сизде.* А.Вергазов

**Хәлсезләнеп киту** Кинәт хәлсезләнү. *Килмешәкнең күңел тибрәнүләре нәтиҗәсендә килеп чыга торган кинәт кенә тирләп, хәлсезләнеп китүе еллар узу белән кимеми, киресенчә, үсеш ала гына бара.* К.Җәмит. *Тик Лилиянең басып торган җиреннән хәлсезләнеп китүен күреп, йөрәгендә бераз кызгану хисе уйнап алды.* Х.Ширмән

**Хәлсезләнеп тору** Гел хәлсезләнү; вакытлыча, берара хәлсезләнү; хәзер хәлсез булу. *Аннары лып итеп урындыкка утырды, байтак вакыт хәлсезләнеп торды да үзәкләрне өзәрлек итеп кычкырып елап җибәрде.* В.Нуруллин. *Эче пошса да, күңеле тулса да, бераз хәлсезләнеп торса да, шуңа барып ябыша.* К.Хәсәнова

**ХӘЛСЕЗЛЕК** *и.* 1) Хәлсез булу; көчсезлек; егәр, куәт, энергия булмау. *Башым әйләнә, бөтен тәнемдә бертөрле хәлсезлек, авырлык сизә идем.* Г.Рәхим. *Кайсысы ачлыктан кибешеп каткан бичараларның, кайсысы, шешенеп, хәлсезлектән кар өстенә ауган да шунда йокыга киткән...* В.Имамов

2) Ярлылык, мохтаҗлык, хәерчелек. *Шушы кризистан соң мин бик хәлсезләндем, һәм бу хәлсезлектән минем хәзергә кадәр чыга алганым юк.* Ә.Еники

3) Авторитеты, абруе, кодрәте, тәэсире тиешле дәрәҗәдә булмау. *Моннан тыш Урданың хәлсезлегеннән Мәскәү дәүләте дә оста файдалана: Сарай шәһәренә генә түгел, болгарларның башка шәһәрләренә дә күп мәртәбәләр яу чаба һәм аяусыз талый.* Т.Әйди. *Әйтерсең лә Рим империясенең хәлсезлеген сизгәннәр.* З.Хәким // Үсеш булмау; артта калганлык. *Ләкин без бүгенге көнгә генә ябышып ятмыйк әле, хәзерге экономиканың хәлсезлегенә, китап басу техникасының артталыгына, ташландык хәлдә булуына аркаланмыйк – зуррак, колачлырак масштабта фикер йөртик.* Ә.Кәримуллин

**ХӘЛФӘ** *и. гар. тар.* Мәдрәсәдә башлангыч һәм урта сыйныфлар укытучысы, имам-мөдәрриснең ярдәмчесе. *Галимҗан исә, киресенчә, әллә нинди сораулар биреп, хәлфәнең үзен аптырата.* С.Поварисов. *Йөгерек санап, ул йөзнең аръягына чыккач, хәлфә: – Җитте, шәкерт! – дип, аны туктатты.* Р.Батулла

**ХӘЛФӘЛЕК** *и.* Хәлфә вазифасы. *Ул аның кайтканын капка төбендә көтеп тормакчы булган иде дә, ләкин үзенең хәлфәлек дәрәҗәсен түбәнсетүдән куркып һәм, аннан да бигрәк, болай арттан калмый йөрүе белән морзаны ачуландырырмын дип уйлап, тиз генә килгән юлыннан кире китеп барды.* М.Галәү

**ХӘЛФӘЛЕ́К ИТҮ** *ф. кит.* Хәлфә вазифасын үтәү, хәлфә булу; укыту. *Хәсәнгата Габәши, мәдрәсә белеме алганнан соң, Казандагы Вәли мулла мәдрәсәсендә хәлфәлек итә.* М.Мәһдиев. *Аннары монда аның улы Исхак, оныгы Ибраһим хәлфәлек иткәннәр.* Л.Хәмидуллин

**ХӘЛФӘЛЕ́К КЫЛУ** *ф. кит. к.* **хәлфәлек итү**. *Мәдрәсәдә уку елларында ул җир сөреп, иген дә игә, баерак шәкертләргә һәм мөгаллимнәргә хезмәтче булып та тора, заводларда, алтын приискаларында да эшләп ала, казах далаларында хәлфәлек тә кыла, кыскасы, Идел-Урал төбәгенең төрле җирләрендә булып, төрле шөгыльһөнәрләрне сынап карый.* Х.Миңнегулов. *Араларыннан Мөхәммәтлатыйф исемле улы заманына күрә яхшы белемле һәм мөхтәрәм зат буларак җитешкән, әүвәле Минзәләбаш мәдрәсәсендә, әтисенә ярдәм итеп, хәлфәлек кылган, балалар укыткан, ахырда шушы ук авылда имамлык иткән.* Ф.Яхин

**ХӘ́ЛЧӘ** *рәв.* Хәлдән килгән кадәр, хәлдән килгәнчә, хәл барынча, кулдан килгәнчә. *Хәлчә түй итәләр.* Безнең мирас. *Авыл җирлеге башлыгы Рамил Муратов, авыл мәчете имамы Госман хәзрәт һәм башкалар аңа һәм аның башлангычын күтәреп алган, хәлчә үз өлешен керткән мәчет картлары, эшмәкәрләр, барлык киң күңелле авылдашларына рәхмәтләрен җиткерделәр.* Йолдыз

**ХӘМЕЛ** *и. гар. иск.* 1) Йөк; күтәреп алып барыла торган нәрсә. *Хәмел ташу*

2) Мәетне күтәреп зиратка озату. *Хәмелгә, мәет күмешергә йөрмисеңме?*

Р.Вәлиев. *Тик менә ул, нишләптер, шәкерт кешегә төшемле нәрсә – җеназага – хәмелгә бармый.* Р.Батулла

3) Мәетне зиратка күтәреп баручыларга бирелә торган садака. *Ул, өч тиен бакыр хәмел садакасы, яисә мәетне кабергә иңдерү сөлгесе өчен, билдән карга чума-чума, үз тормышын корбан итә.* Т.Гыйззәт

4) Көмән, авыр, бала күтәрү. *Хәмел мөддәте бетеп, бер ир бала китердем.* К.Насыйри

5) Юрау, фараз кылу. *Хәмелегез дөреслеккә туры килми*

**ХӘМЕ́Л ИТҮ** *ф. иск.* Юрау. *Нәрсәгә хәмел итәргә бу кайгыны?* Г.Тукай

**ХӘМЕ́Л КЫЛУ** *ф. к.* **хәмел итү**. *Ул моны кемгә дә хәмел кыла алмады.* Г.Ибраһимов. *Миңсылу, иренең токмачтан җитешмәвен аның үпкәләвенә хәмел кылып, аз-аз зәһәрен йота барып, иренә кушталана башлады.* К.Тинчурин

**ХӘМЕЛЛЕ** *и. иск.* Көмәнле, йөкле. *Кызымыз Гайшә хәмелле булып вә вакыты җитдектә бер кыз бала тугдырып, шул баладан вафат тапмыш иде.* Г.Камал

**ХӘМЕЛЧЕ** *и. гар. иск.* Йөк ташучы, йөкче, хәммаль. *Хәмелчеләр янына барып утыр, кемнең йөген күтәреп илтсәң, сиңа дүрт-биш тиен бирерләр.* К.Насыйри

**ХӘМЕР** *и. гар.* Шәраб, аракы, әче бал һ.б. исерткеч эчемлек. *Иртәдән бирле бер тәгамь ризык капмагангамы, хәмер башына тиз китте.* Г.Галиева. *Әллә картның сүзләре шулай каты тәэсир итте, әллә кылган гамәлләре өчен җәза алудан курыкты, Туктар, бер-ике ай авызына хәмер алмыйча, кайчандыр чокырга ауган тракторын төзәтеп маташты.* Х.Ибраһим

**ХӘММАЛЬ** *и. иск. к.* **хәмелче.** *Истанбулга берничә ел мөкаддәм килешемдә, иске идарә заманында, пароход килеп туктар-туктамас, берникадәр тупас һәм гаять начар киенгән хәммаль килеп, «мин алып китәм» дә «мин илтәм» дип тарткалашып, миңа һич сүз сөйләргә ихтыяр бирмәгәннәр иде.* Г.Камал

**ХӘНӘФИ** *и. гар. дини* 1) Ислам динендә дүрт сөнни мәзһәбтән берсе. *Әлеге мәзһәбкә нигез салган Әбү Хәнифә заманында ислам дөньясының үзәге булган Багдадта яшәгән, кешеләр бирегә белем тупларга килгән, шунлыктан нәкъ менә хәнәфи мәзһәбе киң таралыш алган да.* Казан утлары

2) Шул мәзһәбтән булган кеше. *Мәгълүм булганча, бездәге сөнниләрнең күпчелеге хәнәфиләр.* А.Тимергалин. *Мөселманнарны сәләфиләргә, хәнәфиләргә бүлеп, бу хакта артык күп сөйләшү яхшылыкка илтмәячәк.* Ватаным Татарстан

**ХӘНӘФИЛЕК** *и. дини* Хәнәфи мәзһәбе; шул мәзһәбне тоту. *Бу мәсьәлә Диния нәзарәте, дини уку йортлары һәм башка оешмалар дәрәҗәсендә куелса, ваһһаби шәкертләр хәнәфилек турында уйланыр иде.* Р.Мөхәммәтшин. *Хәнәфилекне сайлаганбыз икән, бөтенесе дә шуның буенча эшләргә тиеш.* Безнең гәҗит

**ХӘНБӘЛИ** *и. гар. дини* 1) Ислам динендә дүрт сөнни мәзһәбтән берсе. *Ибн әл-Җәүзи кебек кайбер хәнбәли мәзһәбе галимнәре фикеренчә, дәвалану – хупланган (мөстәхәб) гамәл.* Безнең гәҗит

2) Шул мәзһәбтән булган кеше. *Хәнбәлиләр ширек мәсьәләсенә көндәлек тормышта да зур урын биргәннәр, үткән замандагы яки хәзерге абруйлы руханиларны артык мактау, зиратларга барып сәҗдә кылу, кешеләрне аягүрә торып каршы алуны да гаепләп чыкканнар.* А.Тимергалин. *Шафигыйлар да, маликиләр дә, хәнбәлиләр һәм без үзебезнеке дип санаган Әбү Хәнифәнекеләр дә үзләренекенә өндиләр, һәм монда беркемне дә гаепләп булмый.* Безнең гәҗит

**ХӘНБӘЛИЛЕК** *и. дини* Хәнбәли мәзһәбе; шул мәзһәбне тоту. *Хәнбәлилеккә нигезләнү*

**ХӘНҖӘР** *и. гар.* Ике йөзе дә үткен пычак рәвешендәге очлы салкын корал. *Берәүләр җиңел генә ярадан да аңын җуя, икенчеләр үз тәненә үзе хәнҗәр белән сызып җибәрә – эһ тә итми.* М.Маликова. *Гамьсез егет, кесәсеннән хәнҗәр чыгарып, Аксылуның күкрәгенә кадаган, ди.* З.Мәхмүди

**ХӘРАБӘ** *и. гар.* Җимерек яки җимерелеп, таралып бара торган корылма калдыклары. *Әмма алдымда хәрабәләргә әйләнгән нигезләр, тәмам картаеп, янтайган-егылган өянкеләр, тупыллар күрәм.* И.Юзеев. *Хәрабәләр, ташлар арасында Башын иеп тора кылганнар.* Р.Вәлиев

**ХӘРАҖӘТ** *и. гар. иск.* Чыгым. *Тиешле командировка кәгазьләре бүген үк ясатылса, юл хәраҗәте дә җайланса, яхшы булыр иде.* Ш.Маннур. *Хәзер кайту хәраҗәте зур, килү хәраҗәте дә зур булыр.* Р.Зарипов

**ХӘРӘКӘ** *и. гар.* Гарәп язуында хәрефләр белән күрсәтелмәгән кыска сузыкларны һәм сүзнең башка әйтелеш үзенчәлекләрен белдерә торган юл өсте һәм юл асты диакритик билгеләренең һәрберсе. *«Хәрәкә» сүзе белән гарәп телендә хәреф астындагы һәм өстендәге диакритик билгеләр системасын атыйлар, алар ярдәмендә гарәп язуында кыска сузык авазларны билгелиләр.* Г.Рәхим. *Шуңа күрә кыска сузыклар – гарәп язуы күзлегеннән гомумән сузык аваз түгел, бәлки хәрәкә генә, ягъни тартыкка кушылып йөргән аваз төсмере генә.* Ш.Асылгәрәев

**ХӘРӘКӘЛӘ́Ү** *ф.* Хәрәкәләр куеп чыгу

**Хәрәкәләп чыгу** Баштан ахырга кадәр хәрәкәләү

**ХӘРӘКӘЛЕ** *с.* Хәрәкәләре куелган. *Бу чор истәлекләре текстларында әлиф, уау, йай хәрефләренең хәрәкәле вариантлары күренми.* И.Бәширова. *Хәрәкәле текст*

**ХӘРӘКӘСЕЗ** *с.* **1.** Хәрәкәләре куелмаган. *Бу сүз асылда гарәпчә хәрәкәсез язылыштан алынган һәм дөресе шәүкәлә булырга тиеш.* Р.Әхмәтьянов. *Хәрәкәсез сүз*

**2.** *рәв. мәгъ.* Хәрәкәләрдән башка. *Хәрәкәсез укый белү*

**ХӘРӘКӘТ** *и. гар.* 1) Предметның яки аның кисәкләренең торышы үзгәрү. *Сүз арасында, рюмка, кашыклар хәрәкәте эченнән, Әнвәр һаман Зәлияне күзәтә иде.* Х.Камалов. *Әбү Талиб кәрваны шунда тукталганда, Бәхира Мөхәммәдне күреп, болытларның, кояшның һәм агач ботакларының хәрәкәте буенча аның киләчәктә пәйгамбәр булачагын белеп, бу хакта Әбү Талибка сөйли.* А.Тимергалин

2) Гәүдәнең, берәр әгъзаның торышы, халәте үзгәрү; берәр нәрсә эшләргә теләп яки башка максатлар белән гәүдәне яисә әгъзаларны селкетү, ыргылыш, омтылыш ясау. *Шагыйрь кискен хәрәкәт белән торып ук утырды, юрганы, күкрәгеннән шуып, алдына бөялде.* М.Хуҗин. *Минәт ава-түнә авыр атлап аны куып җитте һәм, капыл хәрәкәт белән Рәниянең беләгеннән эләктереп, тупас итеп үзенә таба әйләндерде.* А.Вергазов

3) Берәр нәрсә әйтергә, аңлатырга теләп, билгеле бер рәвештә аяк, кул, бармак һ.б.ш. әгъзаларны селкетү, кыймылдату күренеше; ым. *Кулларын ике якка болгый-болгый, туктагыз, дигән хәрәкәт ясап, ызгышны сүндерергә тырышты.* Х.Камалов. *Һаман шул*

*бармаклар хәрәкәте белән су эчәргә теләвен, сафсата сатып торуның сукыр бер тиенлек тә фәтвасы юк, дигәнне аңлатты.* С.Поварисов

4) Гәүдәне һәм әгъзаларны алдан билгеләнгән кагыйдәләргә нигезләнеп, билгеле бер үрнәктә, тәртиптә, тизлектә селкетү күренеше (бию, спорт һ.б.ш. тур.). *Урман эченнән чыгып, дүрт күбәләк-кыз, бию хәрәкәтләре ясап, умарталыкка керәләр.* А.Гадел

5) Җисемнең билгеле бер юнәлештә торышын үзгәртүе; шул юнәлештә билгеле ара үтүе. *Йолдыз гыйлеме дигәннән, бик кызыклы күренеш: Казан артының урман эчендәге иң караңгы бер авылында – Күлтәстә яшәгән мулла Шәмсетдин Күлтәси йолдызлар, Кояш, Ай хәрәкәте турында китап язган.* М.Мәһдиев. *Бу әсәрләрдә планеталар хәрәкәте, Ай, Кояш тотылуны билгеләү буенча сызымнар, хисаплаулар китерелә.* Р.Зарипов

6) *филос.* Материянең яшәү ысулы, туктаусыз үсеш-үзгәрештә булуы. *Табигатьнең иркен күкрәгендә Мәңге көрәш, мәңге хәрәкәт, Мәңге туу, Мәңге артып тору белән бергә Үлем-һәлакәт.* Һ.Такташ. *Рухи дөньяда исә пространство, вакыт, хәрәкәт кебек төшенчәләргә урын юк – анда якыны вә ерагы булмаган чиксезлек һәм үткәнгә вә киләчәккә бүленмәгән мәңгелек.* Р.Сафин

7) Юлда, урамда төрле юнәлештә җәяүлеләрнең йөрүе, транспортның үтеп торуы. *Уянып киткәндә, кояш шактый күтәрелгән, урамда хәрәкәт башланган иде инде.* Л.Гыймадиева

8) Нинди дә булса механизмның, машинаның һ.б.ш. эшләп торуы, эшләве, йөреше. *Мотор хәрәкәтен мин йөрәгемнең тибеше шикелле сизәм.* Т.Гыйззәт. *Тракторлар хәрәкәткә килгәч, әйтерсең җил дә туктады, көн дә ачылып китте – җилгә дә, салкынга да хәзер беркем игътибар итмәде.* Н.Фәттах

9) Бер урыннан икенче урынга күчү. *Бу бик уңай иде, дошман безнең сугышчыларның хәрәкәтен соңгы минуткача сизмәячәк.* Г.Әпсәләмов. *Гаяз улы белән урам буйлап хәрәкәтен дәвам итте.* Р.Гаязетдин

10) Җанлылык, ыгы-зыгы. *Гел хатын-кызлардан торган бу бүлмәдә ниндидер моңарчы күрелмәгән хәрәкәтләр бара.* Г.Бәйрәмова. *Ә безнең заман хәрәкәт ярата.* Ф.Баттал

11) Кешенең үз-үзен тотышы, мөнәсәбәте. *Олпат гәүдәле, ак йөзле кырык биш яшьләрдәге Рәфыйкны, электән белмәсәм, кыяфәте һәм хәрәкәте буенча мин һич тә сәүдәгәр дия алмас идем.* Т.Әйди. *Уртакуллар синең һәр хәрәкәтеңне, һәр сүзеңне кабатласыннар, сиңа охшатырга тырышсыннар, киоскларда синең фоторәсемеңә чират булсын...* А.Тимергалин

12) Хәрби берләшмәнең сугыш вакытында алып барган актив сугышчан эшчәнлеге, турыдан-туры сугыш алып баруы; шундый эшчәнлек вакыты; хәрби операция. *Полковник сөйли дә сөйли: бер генә дә акыл өйрәтми, ачыктан-ачык тәрбия белән шөгыльләнми, бәлки сугыш хәрәкәтләре, ничек җиңүгә ирешүләре хакында гына бәян итә.* Н.Әхмәдиев. *Август азагында, Гарифулланы хәрәкәттәге армиягә озатырга дип, Өммегөлсем үзе дә килә алды.* А.Хәлим

13) Берәр төрле эш, эшчәнлек. *Менә шунда кинәт астыртын хәрәкәт башлана.* Г.Ибраһимов. *Сәгыйть тынычлыкны яклау хәрәкәте турында, тынычлык өчен җирдә барган бөек көрәш турында лекция сөйләде һәм ачык итеп, аңлаешлы итеп, чын ораторлар кебек сөйләде.* Н.Фәттах

14) Берәр максатны күздә тотып, оешкан төстә башкарыла торган иҗтимагый эшчәнлек. *Даян ага Мурзин да шул китапның авторы, партизаннар хәрәкәте җитәкчесе С.Ковпак белән бергә сугышып йөргән.* Р.Миңнуллин. *Ләкин бәйсезлек һәм азатлык хәрәкәте үсә, ныгый, тарала, тамыр җибәрә.* В.Юныс

15) Сәнгатьтә, әдәбиятта нинди дә булса яңа таләпләр, яңа максатлар куйган бер юнәлеш. *Иҗат эчтәлекләре төрле характерда булса да, тормыш шартларында аермалар күренсә дә, алар бер хәрәкәт – мәгърифәтчелек хәрәкәте вәкилләре булалар һәм төрле юллар белән искелеккә каршы көрәшәләр, үз халкына хөрлек даулыйлар, аны караңгылык богауларыннан азат итәргә тырышалар.* Я.Абдуллин

16) *әд.* Әдәби әсәрдә вакыйгалар үсеше; вакыйгаларның тиз алышынуы. *Кара-каршы сөйләшүгә корылган мәзәкләрнең күбесе сорау-җавап белән генә төгәлләнми, диалоглар сюжет хәрәкәтен барлыкка китерәләр.* Ф.Хатипов. *Баштарак әсәрдә күпсүзлелек, хәрәкәт азлыгы сизсәм, кәефсезләнә идем.* А.Әхмәдуллин. *Аңа хәрәкәт, вакыйганың үстерелеше, динамизм кирәк.* Г.Шакирова

17) *күч.* Берәр кешенең инициативасы белән башланган эш; нәрсәнең дә булса башлангычы. *XIX гасыр азакларында – XX гасыр башларында бездә хәтта «җәдитчеләр хәрәкәте» булган.* Н.Фәттах. *Пугачёв хәрәкәте бастырылгач, патша ялчылары Торналы авылыннан ике дистәләп кешене Казанга алып китәләр.* А.Тимергалин

**ХӘРӘКӘТ ИТҮ** *ф.* 1) Кыймылдау, кузгалу, селкенү, хәрәкәтләнү. *Болытлар бик тиз хәрәкәт итә, күктә Зур Судагы дулкыннар чагыла.* З.Хөснияр. *Шундый иләмсез зур булуына карамастан, ул бик җиңел һәм җитез хәрәкәт итә, йонлы йомшак койрыгы белән әкрен генә җиргә суккалый.* Р.Мөхәммәдиев

2) Нинди дә булса юнәлештә бару, күчү. *Берән-сәрән генә түгел, оешкан отрядлар хәрәкәт итә.* А.Гыйләҗев. *Истанбулда озак калмаенча, Анкарага хәрәкәт итте.* Х.Миңнегулов

3) Билгеле эш башкару, эшләп тору, йөрү (техника тур.). *Менә ул машинаны кабинада килеш кенә кабызды да өскә таба хәрәкәт итә башлады.* Х.Камалов. *Аларның төп үзенчәлекләре: тимер юл буйлап сәгатенә 100–120 чакрым тизлектә хәрәкәт итүче мондый континентара баллистик ракеталарның кайдалыгын ачыклау, нигездә, мөмкин булмый.* Р.Зарипов

4) *күч.* Нинди дә булса адым ясау, гамәл кылу; эш итү; эшләү. *Чөнки син кайчак эшнең, мәсьәләнең асылына төшеп җитмичә хәрәкәт итәсең.* Р.Батулла. *Россиядәге бүгенге милли сәясәт торгынлыгы чорында татар милли хәрәкәте элитасы республиканың җитәкче даирәләрен татар халкының киләчәк үсеше өчен хәрәкәт итү рухында тәрбияләргә тиешләр.* Р.Вәлиев

5) *күч.* Эш йөртү, нәрсә артыннан булса да йөрү, чарасын күрү. *Мин әйткәнчә, суд аша хәрәкәт итәргә кирәк.* Т.Гыйззәт. *Кыза башласаң, хәрәкәт итәр алдыннан унга кадәр санап, башыңны эшләтә башла.* З.Зәйнуллин

6) *күч.* Үсү, алга китү, яңарып-үзгәреп тору. *Чыннан да, тел хәрәкәт итүдән туктый икән (ягъни функциональ яктан үсми икән), аның структур (ягъни төзелеш) ягыннан үсеше, хәрәкәте дә туктала.* И.Бәширова

**ХӘРӘКӘТЛӘНДЕРҮ** *ф.* 1) Селкетү, кыймылдату, хәрәкәткә китерү. *Шул вакытка туры килсәләр, якыннарым да, ачу китереп, «ялкауланма, сул*

*кулыңны хәрәкәтләндер» дип өстәп торалар.* Т.Галиуллин. *Ул, ике кулын Арслановка таба сузып, бармакларын кызу-кызу хәрәкәтләндерергә кереште.* Ф.Садриев

2) *күч.* Кузгату, тыныч торган хәленнән чыгару, җанландыру. *Минем сүзләрем олырак кызны да хәрәкәтләндерде, күзләренә бераз гаҗәпләнгән кыяфәт чыгарды.* Ф.Әмирхан

**Хәрәкәтләндерә башлау** Хәрәкәтләндерергә тотыну. *Мин өйгә якын ук килдем дә кулларымны ипи ваклаган кебек хәрәкәтләндерә башладым.* Г.Рәхим. *Тәүгиз исә ни дип әйтергә белмәде, гаебе булмаса да кызарып чыкты, шул уңайсызлыгыннан тизрәк арыну өчен, буяу пумаласын тиз-тиз хәрәкәтләндерә башлады.* Х.Камалов

**Хәрәкәтләндерә төшү** Тагын бераз хәрәкәтләндерү. *Бармакларын хәрәкәтләндерә төште*

**Хәрәкәтләндереп алу** Бераз гына хәрәкәтләндерү. *Кыз, розаларны иркәләгәндәй, чәчәкләр өстеннән җиңелчә генә кулын хәрәкәтләндереп алды.* Ф.Яруллин. *– Ни йомыш соң, абзый? – дип сорады башлык, әйләнмәле урындыгын җай гына хәрәкәтләндереп алганнан соң.* Р.Низамиев

**Хәрәкәтләндереп җибәрү** Бераз, беркадәр хәрәкәтләндерү; кинәт хәрәкәтләндерү. *Ул үзен көчләп диярлек шул дөнья мәшәкатен чакырып китерергә, аулакта бер тәртипкә салып карарга теләде, ләкин алар барысы кайдадыр еракта оеганнар, үзләрен кузгатырга, хәрәкәтләндереп җибәрергә һич мөмкин түгел.* А.Вергазов

**Хәрәкәтләндереп кую** Бер тапкыр хәрәкәтләндерү. *Сирәк-мирәк кулларын хәрәкәтләндереп куя.* Ф.Яруллин. *Минем нидер әйтергә теләп кыбырсуымны күреп, ул дәү кулын хәрәкәтләндереп куйды: тыныч кына утыр, янәсе.* Р.Зәйдулла

**Хәрәкәтләндереп тору** Даими, һәрвакыт хәрәкәтләндерү; әле, сөйләп торганда хәрәкәтләндерү. *Тезең катмасын, хәрәкәтләндереп тор, дигән.* Ф.Яруллин. *Битләренә каккалап, кулаякларын хәрәкәтләндерә торгач, шофёр егет күзләрен ачты, кыймылдап куйды.* А.Вергазов

**ХӘРӘКӘТЛӘНҮ** *ф.* 1) Нинди дә булса юнәлештә, бер урыннан икенче урынга бару, күчү, хәрәкәт итү. *Базарда кычкырып сөйләшүчеләргә кытлык юк, игътибар итмичә, алга табан хәрәкәтләнәбез.* Н.Әхмәдиев. *Кыскасы, бронза чорыннан башлап гасырлар буена дигәндәй, атлы, арбалы, коралды качаклар, башлыча гаскәриләр, буш, аулак җирләргә таба хәрәкәтләнгәннәр.* Н.Фәттах

2) Хәрәкәттә булу, хәрәкәт ясау; селкенү, кыймылдау. *Кайчак кискен хәрәкәтләнгәндә генә, мәче баласының үткен тырнаклары тәненә тиеп-тиеп ала иде.* З.Хөснияр. *Өстемдәге киемем җылы, хәрәкәтләнгәндә тирлим, аннары шул килеш март кары өстендә сәгатьләр буе ятарга туры килә.* Л.Гыймадиева

3) Хәрәкәт ясарлык сәләте булу. *Ул күзләрен ачты, ләкин хәрәкәтләнә дә, тора да алмады.* Г.Исхакый. *Өянәгеннән соң Саимәнең сул кулы хәрәкәтләнә алмый иде, ул сәламәт кулы ягында басып торган Аниягә үрелде: – Кызым, бәгырь парәм минем! Кил әле якынрак...* Г.Галиева

4) Кузгалу, җанлану, ыгы-зыгы килә башлау. *Ул вакытта йорттагы кешеләрнең ничек хәрәкәтләнүен, чабышуын күрсәң син!* Р.Вәлиева

5) *күч.* Эшчәнлек алып бару, гамәл кылу, нәрсәдер эшләү; яшәү. *Халык бик гади төшенчәләр белән фикер йөртә, көндәлек вазгыятькә карап хәрәкәтләнә.* Р.Зәйдулла. *Һәрнәрсәне төптән уйлап, ашыкмый гына хәрәкәтләнергә өйрәнгән Эдуард эшенең барып чыгачагына шикләнми иде.* А.Гыймадиев

**Хәрәкәтләнә башлау** Хәрәкәтләнергә керешү. *Зарифа инде бөкрәеп, таякка таянып кына хәрәкәтләнә башлаган иде.* Р.Мөхәммәдиев. *Шулчак аларның артыннан ук диярлек йорт янына кечерәк автобус та килеп туктады, аннан ак халатлы кызлар, апалар төште, һәм барысы да кырмыскалар кебек кайнаша, хәрәкәтләнә башлады.* З.Хөснияр

**Хәрәкәтләнә тору** Даими, һәрвакыт хәрәкәтләнү, озак вакыт дәвамында хәрәкәтләнү. *Мөслимә карчыкның кулы көлчә салынган коштабак белән авыз тирәсендә байтак хәрәкәтләнә торгач арыды, ахры, аның авыз чапылдатуы сирәгәйде.* Л.Лерон

**Хәрәкәтләнә төшү** Тагы да ныграк хәрәкәтләнү. *Хәрәкәтләнә төшкән саен аякларының катырак сызлавына игътибар итте ул.* Кызыл таң

**Хәрәкәтләнеп алу** Бераз, берара хәрәкәтләнү. *Бик үк калын киенмәгән сугышчылар, салкынга бирешмәс өчен, әледән-әле хәрәкәтләнеп алырга мәҗбүр булды.* Т.Әйди. *Чү! Бер шәүлә хәрәкәтләнеп алды түгелме?* Н.Хәсәнов

**Хәрәкәтләнеп кую** Бер тапкыр хәрәкәтләнү. *Ирекнең кызарган күзләре зураеп киттеләр һәм хәрәкәтләнеп куйдылар.* Ф.Садриев. *Аның исеме әйтелү белән, залдагылар хәрәкәтләнеп куйдылар.* С.Поварисов

**Хәрәкәтләнеп тору** Әле, сөйләп торганда хәрәкәтләнү; даими, һәрвакыт хәрәкәтләнү. *Гафур Кәрамов – уртачадан калку буйлы, таза, базык кеше, сөйләшкәндә, калын кашлары бертуктаусыз хәрәкәтләнеп тора.* А.Гыйләҗев

**ХӘРӘКӘТЛЕ** *с.* 1) Хәрәкәтләнә торган. *Кәгазь янып беткәндә, кәгазь көлләре ак морҗада хәрәкәтле рәсемнәр хасил итә.* Р.Зарипов // Билгеле рәвештә хәрәкәт итә торган. *Сәхнәдә очып кына йөрүче нечкә билле, нәфис хәрәкәтле элекке Мәдәния яңадан күз алдына килеп басты.* Г.Бәширов. *Яше алтмыштан узган булса да, җитез хәрәкәтле, көчле-куәтле кеше иде Солтангали абзый.* Г.Гомәр

2) Хәрәкәт күп булган, хәрәкәттән гыйбарәт. *Бала йөри, уйный башлагач, аның тормышына төрле хәрәкәтле уеннар килеп керә, баланы табигать белән якыннанрак таныштыру вакыты килеп җитә.* Л.Минһаҗева. *Хәрәкәтле уеннарга басарга, экскурсияләргә барырга бөтенләй теләкләре юк аларның.* Кызыл таң

3) Ниндидер җанлылык хөкем сөргән. *Коридор бераз шау-шулы һәм хәрәкәтле иде.* А.Шамов. *Өй эче бүген аеруча хәрәкәтле: барысы да әзерләнә, тыз-быз килә.* Р.Вәлиев

**ХӘРӘКӘТСЕЗ** *с.* **1.** 1) Хәрәкәтләнми, кымшанмый торган. *Тоныкь, хәрәкәтсез, кайнар күз алмаларын күреп имәндем...* А.Гыйләҗев. *Аның йөзе таш шикелле хәрәкәтсез, салкын көе калды.* В.Имамов

2) *күч.* Җансыз. *Булат абзый, елама, җылы кочагы насыйп булмаса да, салкын гәүдәсен, хәрәкәтсез йөрәген минем өемә алып кайтыйк.* Т.Гыйззәт. *Чалкан яткан хәрәкәтсез гәүдәне төрлечә тикшереп карагач: «Тәгаен, ул үлмәгән. Клиник үлем бу», – дигән карарга килде.* Н.Каштанов

**2.** *рәв. мәгъ.* Селкенмичә, кыймылдамыйча. *Дилбәр аның «иде»сен ишетмәде булса кирәк, күз карашында да, иреннәре торышында да бернинди үзгәреш сизелмәде, җавапка канәгатьләнгәндәй, шулай сабыр, кайгылы килеш хәрәкәтсез ята бирде, әкренләп сулышы тигезләнде.* Г.Әпсәләмов.

*Барый беркавым тәрәзәгә таба карап хәрәкәтсез утырды да кинәт утырган урынында кымшанып куйды һәм, кипкән иреннәрен ялаштыра-ялаштыра, миңа төбәлде.* З.Хөснияр

**ХӘРӘКӘТСЕЗЛЕК** *и.* 1) Хәрәкәт булмау хәле, тикторыш. *Бу тынлык, бу хәрәкәтсезлек шулкадәр тирән иде ки, хәтта минем сулыш алуым табигатьнең бу бөек тик торуын боза кебек тоела иде үземә...* Ә.Еники. *Организмны эш, хәрәкәт туздырмый, киресенчә, хәрәкәтсезлек харап итә, күп ашау-эчү, май басу бетерә.* Г.Хөсәенов

2) *күч.* Җансызлык, тынычлык. *Бу үзгәрешсез ак төс, бу хәрәкәтсезлек Мөниргә тәмам туйдырды.* Г.Әпсәләмов. *Эшсезлектән, хәрәкәтсезлектән тәне сизрәп бара.* Ф.Сафин

3) *күч.* Эшсезлек, инициативасызлык, ялкаулык. *Куркаклык – эшсезлеккә, хәрәкәтсезлек торгынлыкка илтә.* Ш.Галиев. *Шушы йомылуы ниндидер хәрәкәтсезлек, катып калганлык тойгысын тудыра.* Л.Шагыйрьҗан

**ХӘРӘКӘТЧӘН** *с.* 1) Күп хәрәкәт итә торган, тынгысыз. *Көндез арып ял итәргә туктаган шушы караңгы җир өстенең, ерактагы тау карачкыларының, хәрәкәтчән шул болытларның үзара әкрен генә пышылдашуларын, авыр уфылдап тын алуларын ишетә кебек тоелды.* Н.Фәттах. *Аның сизгер, нечкә, хәрәкәтчән бармаклары готовальняның кызыл бәрхете эчендә ялтырап яткан ак тимер каләмнәргә һәм җәзбәләргә җан өргәндәй итәләр.* М.Маликова

2) Җиңел гәүдәле, җитез (кеше тур.). *Мәгъсүм хәзрәт кәҗә сакаллы, бәләкәй генә гәүдәле, бик хәрәкәтчән, тере карт булып чыкты.* А.Тимергалин

3) Җанлы; еш үзгәрүчән (йөз, күз хәрәкәтләре тур.). *Гыйлемдар компьютер белән мәш килгәндә, Ак әби аның яныннан китмәде һәм, малайның хәрәкәтчән йөз сызыкларына карап, аның ничек тәэсирләнүен, балаларча куануын күзәтеп, кичерешләрен чыраеннан укып торды.* А.Тимергалин. *– Минем илле яшькә ник бернәрсә дә бирмәдегез? – дип, Мөдәррис хәрәкәтчән күзләрен әле Марсельгә, әле Равил Фәйзуллинга төбәде.* Л.Лерон

**ХӘРӘМ** I *с. гар. к.* **харам**. *Хәрәм эчемлекне, шуның белән сыйланырга тотынган татарларны күргәч, комиссия шаккаткан һәм көне-сәгате белән Фарук патшага «Без монда мөселманнарны очратмадык» дип телеграмма суккан.* Т.Әйди. *Хәләл көчең белән яшәргә насыйп итсен, Ходай сине хәрәм малдан сакласын, амин, дигәннәре рас килде...* К.Кәримов

**ХӘРӘМ** II *и. гар.* 1) Күпхатынлылык булган мөселман халыкларында хатыннар ягы, хатыннар бүлмәсе, бинасы; гарем. --- *һәр тар-мар ителгән илнең иң гүзәл бикәчләрен үз хәрәменә тутырган Тимер әмир чынлап та хәйран калган иде.* Р.Батулла. *Сак кына кагылды император зифа сынга, каршылык күрсәтмәсенә иманы камил иде – хәрәмдәге кәнизәкләр ханга каршы килми!* Р.Камал

2) Шундагы хатын-кыз һәм җарияләрнең һәммәсе. *Солтанның бөтен хәрәме бәйрәмгә чакырулы иде*

3) *биол.* Бер иркәк хайванга карата теше хайваннар төркеме. *Әтәчнең хәрәме. Айгырның хәрәме. Хәрәм гаиләсе*

**ХӘРӘМ АГАСЫ** *и.* Хәрәм II (*1 мәгъ.*) сакчысы. *Дөрес чамалаган булсам, сарайның эчке ишегалды да булырга тиеш, күпсанлы кәнизәкләр, ят ирләр күзеннән качып, хәрәм агалары күзәтчелегендә шунда гына ял итә торганнардыр, күрәсең.* А.Тимергалин. *Кытай императоры шунда ук үзенең кызын аңа хатын итеп җибәргән, аны хәрәм агасы озата килә.* Р.Хәкимов

**ХӘРӘМЗӘ** *и. гар.-фар. иск.* 1) *к.* **харамзадә**

2) Ялганчы, алдакчы, хәрәмче. *Акылсызны катыштырсаң, уен бозар, хәрәмзәне катыштырсаң, җыен бозар.* Н.Исәнбәт

**ХӘРӘМЛӘ́Ү** *ф. сөйл.* 1) Алдау, ялганлау. *Бу зыянны булдырмас өчен, без папирос көпшәсен төйгән яфрак белән тулыландыра төшәбез, ә бу хәрәмләү бер дә яхшылыкка китерми иде.* Т.Нурмөхәммәтов. *Юк, хаҗи белән абыстай беркадәр хәрәмлиләр, моны үзләре дә яхшы белә иде.* В.Имамов

2) Хәйләләү. *Дөрес, әти бераз хәрәмли: безгә сыеграгын ясый.* Т.Галиуллин. *Мин ота башласам, син гел хәрәмлисең, юкка сәбәп табасың.* А.Гадел

**Хәрәмләп алу** Бераз хәрәмләү. *Уяу булмасаң, хәрәмләп алудан да кыенсынмый ул.* Мәйдан

**Хәрәмләп тору** Әледән-әле яки хәзер хәрәмләү. *Хәрәмләп торуыңны сизмиләр дисеңме?* Р.Вәлиева

**Хәрәмли башлау** Хәрәмләргә керешү. *– Хәрәмли башлаганыңны сизсәк, шунда ук уеннан чыгарабыз, – дип кисәтте аны абыйсы.* М.Вәлиев

**Хәрәмли төшү** Беркадәр, бераз хәрәмләү; тагын да күбрәк хәрәмләү

**ХӘРӘМЛӘШҮ** *ф.* 1) Алдау, ялганлау. *Берничә көн алдан җыелды, дип языла икән, монда хәрәмләшү юк.* Х.Камалов. *Җирдәгеләр сайлауларда хәрәмләшә, саклан, Онык!* Н.Гыйматдинова

2) Хәйләләү. *Гыйбадулла чулак, чөгендер төсле кызыл танавын селкетә-селкетә: – Хәрәмләште, хәрәмләште! Нәселе шундый, хәйләкәр! Хәрәмләште! – дип акыра.* А.Гыйләҗев. *Бу көрәштә кагыйдә юк: Хәрәмләш, аяк та чал.* Ф.Яруллин

**Хәрәмләшә башлау** Хәрәмләшергә тотыну. *Бераз хәрәмләшә башласалар: – Булдыксызлар! – дип кычкыра ул, таягын болгап. – Һаман уртада кайнашмасагыз!..* Ф.Җамалетдинова

**Хәрәмләшеп алу** Тиз арада хәрәмләшү. *Ярый, бераз хәрәмләшеп алдык та – җиткән.* А.Баймөхәммәтов

**Хәрәмләшеп карау** Хәрәмләшергә тырышу, хәрәмләшү алымын сынау. *Хәрәмләшеп тә карадым − Тик барыбер ул җиңде.* Ә.Моталлапов. *Тик апалар, абыйлар Чүлмәк вата алмыйлар: Хәйләләшеп карыйлар, Хәрәмләшеп карыйлар, Чүлмәкнең кайдалыгын Белергә тырышалар, Күрергә тырышалар.* Р.Миңнуллин

**Хәрәмләшеп тору** Әле, хәзерге вакытта хәрәмләшү; әледән-әле, даими хәрәмләшү. *Картаеп беткәч кенә хәрәмләшеп тормам инде.* Ә.Галиев

**Хәрәмләшеп яту** *сөйл.* Озак вакыт дәвамында хәрәмләшү. *Ә монда Гелашвили хәрәмләшеп ята.* И.Диндаров

**ХӘРӘМЛЕК** *и. к.* **харамлык**. *Байларның һәр җирдә дә сүзе үтеп, кулы уйнаганга, су башлыгы аларга хәрәмлек эшли алмый иде.* Н.Сәфәров. *Ришвәт малның хәрәмлегенә, хәләллегенә игътибар итмәүдән башлана.* Татарстан яшьләре

**ХӘРӘМЧЕ** *и.* 1) Берәр уенда алдашып, хәрәмләшеп, хәйләләп уйнаучы; алдакчы. *Ах, хәрәмче, курыктыңмыни?* Н.Исәнбәт

2) Хәрәм эшләр белән шөгыльләнүче. *Каютага керү белән, борсаланып, ризасызлык белән үзалдына мыгырдый башлады: «Кара син хәрәмчене, нинди түрә булган, сугымга симертелгән чучка кебек тәмам бүртенгән».* С.Сабиров

**ХӘРБИ** *с. гар.* **1.** 1) Армия хезмәтендәге; армиядә хезмәт итү белән бәйле; гаскәри. *Хәрби ир башына яшел пилотка кигән, анда кызыл йолдыз янып*

*тора, өстендә яшел гимнастёрка, галифе чалбар, аягында – олы юл тузанына чумган күн итек.* Н.Каштанов. *Өч шакмаклы башлык кыңгырау шалтыратуга, бүлмәгә әзмәвердәй гәүдәле ике хәрби кеше килеп керде.* В.Имамов

2) Армия белән бәйле, хәрби эшләр өчен билгеләнгән; гаскәриләргә караган, алар өчен эшләнгән. *11 сентябрьдә Ташкенттан хәрби поезд белән чыгып китеп, 14 сентябрьдә иртән Фрунзе Көньяк фронтының штабы урнашкан Харьков каласына килеп җитә.* З.Зәйнуллин. *Кайчандыр хәрби самолётлар өчен катлаулы электроника җитештергән, озак еллар гөрләп эшләп торган, заманында үзем дә хәтсез хезмәт куйган завод территориясенә әләгеп, андагы хәрабәләргә әйләнгән цехларны күргәч, көчле тетрәнү кичергән идем мин.* Н.Шәрифуллин

3) Шул юнәлештә белгечләр, гаскәриләр әзерли торган. *Аннары Мөнирә ят бер тавыш белән: – Хәрби мәктәпкә китү фикереңне үзгәртмәдеңме? – дип сорады.* Г.Әпсәләмов. *Алсаф, әтисе кебек үк, хәрби училище тәмамлаган, бераз хезмәт итеп тә өлгергән икән һәм, көтмәгәндә, биредәге хәрби комиссариатка эшкә килеп урнашкан.* З.Мурсиев

4) Сугыш кирәк-яраклары, оборона кораллары җитештерә торган. *Әнвәр абый Казанга барып, хәрби заводта токарь өйрәнчеге булып эшләргә урнашып кайтты.* А.Хәсәнов

**2.** *и. мәгъ.* Армия хезмәтендәге кеше; хәрби кеше, гаскәри. *Илдарның гәүдәсен китерә килгән хәрбиләр әллә ни аңлатып маташмадылар.* А.Әхмәтгалиева

**ХӘРБИЛӘ́РЧӘ** *рәв.* Хәрби кешеләр кебек; хәрбиләргә хас булганча, гаскәриләрчә. *Хәзер, зонага баш агроном итеп билгеләнгәч, армиядә бер көн хезмәт итмәвенә карамастан, бер кулын чигәсенә күтәреп, хәрбиләрчә саубуллаша башлаган.* Г.Әпсәләмов. *Хезмәт тәмам! Өйгә кайтыш, Аяклар җиргә тими. Хәрбиләрчә атлаганда, Кайтасы юл сизелми.* Х.Бәдигый

**ХӘРБИЛӘШТЕРҮ** *ф.* 1) Сугыш шартларына җайлаштыру, сугыш кирәк-яраклары җитештерүгә күчерү, милитаризацияләү. *Хәрбиләштергән леспромхозда урман кисүче әнием, сугыш беткәнчегә кадәр, ай саен «военный паёк» ала иде.* Ф.Сафиуллин. *Сәнәгатьне хәрбиләштерү*

2) Нәрсәне дә булса хәрби хәлгә, формага кертү, хәрбиләрчә итү. *Егетләр хәзергә өс-башларын хәрбиләштерүне дәвам иттерделәр.* Г.Гобәй. *Экспертлар, кризис вакытында дәүләт җитәкчелеген хәрбиләштерү бара, дип саный.* Л.Харрасова

**Хәрбиләштерә башлау** Хәрбиләштерергә тотыну

**Хәрбиләштереп бетерү** Барысын да хәрбиләштерү, тулысынча хәрбиләштерү, хәрбиләштерүне төгәлләү. *Заводны хәрбиләштереп бетерү*

**Хәрбиләштереп килү** Озак вакытлар дәвамында аз-азлап хәрбиләштерү. *Сәнәгатьне хәрбиләштереп килү*

**ХӘРБИЛӘШҮ** *ф.* 1) Сугыш шартларына җайлашу, сугыш ихтыяҗларын тәэмин итүгә күчү. *Завод-фабрикалар хәрбиләшү*

2) Хәрби формага керү, хәрбиләрчә эш итү, хәрбиләргә хас гамәлләр кылу. *Хәрбиләшкән яшь егетләр*

3) Хәрби хезмәткә керү, хәрби кеше булып китү. *Шишмә, Зәй сулары аралыгына күчерелгән ул ярым хәрбиләшкән «казак»лар авылларының оешкан төстә берничә полкка берләшүе мәгълүм.* Л.Хәмидуллин

**Хәрбиләшә бару** Вакыт узган саен ныграк хәрбиләшү. *Шулай итеп, Русия елдан-ел хәрбиләшә бара.* М.Хафизов. *Иван Рыбкин хакимиятнең «хәрбиләшә баруына» борчылуын белдерә.* Татарстан яшьләре

**Хәрбиләшә төшү** Тагын да хәрбиләшү

**Хәрбиләшеп бетү** Бик нык хәрбиләшү, тәмам хәрбиләшү

**ХӘРДӘЛ** *и. гар. к.* **горчица**. *Мендәр астына кыстырып куелган ят маузер, ипи телеменә сылангaн хәрдәл – горчица шикелле, ул уйларга нервларны кытыклый торган аерым бер хасият өстәде.* Т.Әйди. *– Әй углым, – диде Локман, – (игелекме ул, яманлыкмы) кылмышың хәрдәл (гәрчич) бөртеге хәтле генә булып, ул да тау кыясына яки күкләргә, яки җир астына яшерелгән булса да, Аллаһ (Кыямәттә) аны синең каршыңа чыгарып куяр.* Р.Батулла

**ХӘРЕҖ** *и. гар. иск.* Чыгым, расход, хәраҗәт. *Хаммам хәреҗенә дүрт йөз акча бирмешләр иде.* М.Гайнетдин. *Мәскәүгә ел саен 740 ар миллиард сум хәреҗ дәрьясы озатып торабыз бит.* Мәдәни җомга. *Туй хәреҗе. Юл хәреҗе*

**ХӘРЕФ** *и. гар.* Авазның язудагы билгесе, аваз тамгасы, аваз билгесе. *Алфавитның башка хәрефләре – Һәммәсе дә минем дусларым.* И.Юзеев. *Бик мавыктыргыч – хәреф тезеп, сүз төзеп уйныйсың.* С.Шәрипов

◊ **Хәрефкә хәреф** 1) Сүзен сүзгә. *Утызынчы елларда – иҗадилык хупланмаган, инструкцияләргә, догмаларга ябышып яткан елларда – бу шаукым хәрефкә хәреф тәрҗемә итүгә, ягъни механик ысулга ябышын яту чиренә китерде.* И.Низамов. *Бу органнарның татарча исеменә русларныкындагы «по»ны хәрефкә хәреф, сүзгә сүз тәрҗемә итүдән генә килеп кергән.* Кызыл таң; 2) Җентекләп, төгәл итеп, детальләп. *Булган хәлне хәрефкә хәреф сөйләп бирү.* **Хәрефкә хәрефне ялгый белү** Аз-маз укый-яза белү. *Хәрефкә хәрефне ялгый белә башлаган идек, егетләребез безне өйрәтеп тә тормыйлар.* М.Әмир. **Хәрефкә хәреф туры килү** Нәкъ, төгәл, дөрес булу. *Художество әсәрләрен тәрҗемә итү ул – хәрефне хәрефкә туры китереп, механик рәвештә сүзне сүзгә аударып утыру дигән сүз түгел.* М.Җәлил. *Галим үзе әйткәнчә, тәрҗемә сүзгә сүз, хәрефкә хәреф туры китерелгән булса да, ичмасам аз гына да төп нөсхәгә якынлаша алмый, аның кабатланмас аваз симфониясен, кешеләрдә күз яше чыгарырлык хәйран калу, гаҗәпләнү тудыра алмый.* М.Галләм. **Хәрефкә ябышып яту** Мөһим мәсьәләләрне аңламыйча, вак-төяккә күбрәк игътибар юнәлтү; ваклану; артык вак эш белән шөгыльләнү. *Әлегә дини текстның мәгънәсенә төшенмичә, хәрефкә ябышып яту күзәтелә.* Мәдәни җомга. **Хәрефкә ябышып ятучы** Эшнең, мәсьәләнең тышкы ягына, вак-төякләренә игътибар итеп, аның төп мәгънәсенә, асылына зарар китерүче; формалист. *Хәрефкә ябышып ятучылардан тагын нәрсә көтәсең инде...* Идел. **Хәреф колы** *к.* **хәрефкә ябышып ятучы**. *Бу эш белән турыдантуры шөгыльләнергә тиешле татар укытучысы хәзер тел мәсьәләсендә иң консерватор даирәгә әйләнде – гомер буе эшләмәгән эшкә дә хисап яздыртып, кәгазь чаралар үткәртеп аның теңкәсенә тиеп, хәреф колына, рәсми инструкцияләргә табынучыга әйләндерделәр, ул алга карауны, яңалыкларны хуплауны үзенә артык хезмәт, мәшәкать дип санарга күнеккән.* Ватаным Татарстан. *Республика җитәкчесе әлеге хәлне «формальлектән котылу, хәреф колы булудан туктау» дип бәяләде.* Туган як. **Хәреф тану** Бераз укый белү. *Абыстайга йөрүче сирәк кызларга гына хәреф*

*тану, мөстәкыйль укуны үзләштерү рөхсәт ителгән.* Л.Хәмидуллин. *Кырык яшьлек хәзрәт мулла гына түгел, ярты авылның хәреф танырга өйрәткән хәлфәсе дә иде шул!* Г.Әдһәмова

**ХӘРЕ́Ф ҖЫЮЧЫ** *и. махс.* Типография хезмәткәре, наборщик. *Менә шушы Ральф төннәрен типография шрифтларын чәчеп ташлый, хәреф җыючыларны интектереп, күзгә бик чалынмый торган җирләрдә әкәмәт хаталар һәм башка ляпсуслар ясап куя, имеш.* А.Тимергалин. *Хәреф җыючыларның язмаларны металл калып рәвешенә китергәнче күп күз нуры түгелә.* Р.Зарипов

**ХӘРЕФЛЕ** *с.* Хәрефләр белән билгеләнгән, хәрефләр ярдәмендә тасвирланган. *Хәрефле билгеләмә. Хәрефле тигезләмә. Хәрефле формула*

**ХӘРЧӘҮНӘ** *и. рус к.* **харчевня**. *Сабирҗан кибеткә кереп кирәк әйберләрен алган арада, Сәмигулла абзый хәрчәүнәдән яхшы гына кәефләнеп чыкты.* М.Хәсәнов. *Киттек берәр хәрчәүнәгә, тамак ялгап, чәйләп тә алырбыз.* Р.Мөхәммәдиев

**ХӘСИС** *с. гар. кимс.* **1.** Әшәке, начар, түбән, шакшы. *Гомер буе яхшылык кыл – хәсис бәндә Юк бер үпкә өчен барсын ташлар сызып.* Р.Корбан. *Хәсис затның йөзен ачкач, күңелемә шик килде, – болай әйтеп, Җирнең үзен үпкәләттем шикелле.* З.Мансуров

**2.** *и. мәгъ.* Әшәке, начар кеше. *– Аһ, нәләт! Аһ, хәсис! – дип чәчрәп чыга моңа кадәр көчкә түзеп торган Светлана.* Э.Шәрифуллина. *Хурлыгыннан авылдан ук чыгып сызган, хәсис.* З.Мәхмүди

**ХӘСИСЛЕК** *и.* Хәсис булу сыйфаты; түбәнлек, әшәкелек. *Чөнки мондый да хәсислекне уйлаучыларны алай гына денгә кертеп булмас.* Р.Фәизов. *Ул көнчелек, ул хәсислек илдә, Ул минминлек һәм дә сукырлык – Яши-яши шушы хәлләрендә, Алар белән без дә убылдык.* Ф.Яхин

**ХӘСИТӘ** *и. гар. этн.* Хатын-кызлар өчен алтын-көмеш акчалар, ука һәм төрле кыйммәтле ташлар белән бизәлеп, күлмәк өстеннән күкрәккә киеп куела торган затлы бизәнү әйбере. *Чынаяктай ак муенында гәрәбә төймә, хәситәсендә асылташлар җемелди, беләзеге күзне тартып тора.* М.Хәбибуллин. *Егерме беренче елгы ачлык вакытында шул хәситәсенең алтын-көмеш тәңкәләрен кайдадыр икмәккә алыштырып, ярты авылны ач үлемнән алып калган, дип сөйлиләр иде аны.* Н.Көбәш

**ХӘСРӘТ** *и. гар.* **1.** 1) Авыр кайгы, зур көенеч, тирән борчылу, әрнү хисе. *Хәсрәт хәсрәткә охшамый, баш хәсрәттән бушамый, дигәндәй, Газинурның үз башына үз теләге белән алган хәсрәт бу.* А.Хәсәнов. *Синең шатлыгың да, хәсрәтең дә яшерен.* Г.Бәйрәмова

2) Бәла-каза, бәхетсезлек, тирән кайгыга сала торган вакыйга. *Шул фикерле, шома егетебез Безгә күпме хәсрәт китерде.* И.Юзеев. *Бер хәсрәт берләштергән ике ата озак утырдылар.* Г.Галиева

3) «Җан көеге», «имгәк» мәгънәсендә ачулану, тиргәү сүзе булып кулланыла. *Әй, хәсрәт, тот, күп телеңә салынма!* Х.Камалов. *Син, тере хәсрәт, Айсылуны кем үтерде?* Р.Сәгъди

**2.** *с. мәгъ. кимс.* Эшен бик яхшы башкармый торган, башкаларга борчумәшәкать тудыра торган; хәерсез, мескен. *Көчем җитмәгәнне күреп, теге хәсрәт балыкчы да булыша башлады!* З.Мәхмүди. *Үзең гаепле бөтенесенә дә, хәсрәт укытучы!* Р.Камал

◊ **Хәсрәт капчыгы** Борчу-хәсрәте күп булган, башкаларны да борчуга сала, мәшәкать тудыра торган кеше. *Шәехгалинең хәсрәт капчыгы икәнен белә торып, һаман шуны төртергә тырыша бу Василий ---.* М.Әмирханов. *Хатын: «Йөрисең инде, хәсрәт капчыгы, илле икегә җитеп бер китап чыгара алмыйча», – ди.* А.Хәмзин. **Хәсрәткә бату** Кайгыру, борчылу; нинди дә булса кайгыга, борчу-мәшәкатькә дучар ителү, хәсрәтле булу. *Ул көннәрдә әнинең күз яшьләре түгеп, хәсрәткә батып йөргәне хәзер дә бик яхшы хәтеремдә.* В.Нуруллин. *Әмма Хәдичә, әллә нинди изге бер көнчелек һәм кайгыртучанлык белән, аның нишләп йөргәнлеге хакында уйлап хәсрәткә бата.* Ф.Яхин. **Хәсрәткә батыру** *к.* **хәсрәт утына салу**. *Үзен бәхетле итәм дип, мине дә, үзен дә хәсрәткә батырачак бит, хәсрәткә батырачак.* Р.Харис. *Хәсән Сарьян иҗат иткән мәһабәт гәүдәле геройлар, кырау суккандай, аналарын хәсрәткә батырып, якты дөньядан китеп бара.* Р.Рахман. **Хәсрәткә төшү** *к.* **хәсрәткә бату**. *Икебез дә тирән хәсрәткә төштек, мәктәп иминлеге өчен дә курка башладык.* А.Гыйләҗев. **Хәсрәттән башы чыкмау** Бик күп кайгыхәсрәт күрү. *Ни хикмәттер, хәсрәттән башы чыкмаган, фани дөньядан бик яшьли китеп барган, әмма кыска гына шул гомерендә дә искиткеч әйбәт вә камил әсәрләрен безгә мирас итеп калдырган шагыйрьнең пластик образын табу мәшәкате, иҗади эзләнүләр белән мавыгып китү нәтиҗәсендә бераз онытыла, кайгылы кара уйлардан акрынлап арына башлаган сыман булды.* К.Миңлебаев. **Хәсрәт төенчеге** *к.* **хәсрәт капчыгы**. *– Бүрек белән яулык дигән була, хәсрәт төенчеге, – дип, ирен читләре кыяр-кыймас кына җәелде Кәрләбикәнең.* Л.Закиров. *И-и, җаным, яшьнеке яшь шул, куллары да мамык шикелле, дигән була, хәсрәт төенчеге.* Безнең гәҗит. **Хәсрәт утына салу** Борчу-мәшәкать тудыру, кайгыхәсрәт китерү. *Ни хакым бар иде минем әниемне мондый хәсрәт утына салырга, әтиемне яртылаш картайтырга?* Ә.Еники. **Хәсрәт утында яну** Бик нык кайгыру, борчылу. *Мәрьямбану иртәгәсе көн өчен хәсрәт утларында янмыйча, бүген булганына сөенеп, шөкрана кылып яшәргә өйрәнде.* Ф.Бәйрәмова. *Илсөяр кияүгә чыгып Казанга киткәч, ул, хәсрәт утында янып, айнымады да диярлек.* З.Мәхмүди. **Хәсрәт чигү** Борчылу, кайгыру, хәсрәтләнү. *Юктыр, менә ул гомер иткән картына эчәргә дип сөт җылытып йөри, аның авыруына, чын күңелдән булса кирәк, хәсрәт чигә, бүлмә тактасының теге ягында ул мышык-мышык елап та ала, Вәли карт моны ишетеп ята, дәшми...* М.Мәһдиев. *Уңышларыбыз булса да шунда җыелып шатланабыз, хәсрәтебез булса да шунда бергә хәсрәт чигәбез.* С.Ибраһимова

**ХӘСРӘТЛӘНДЕРҮ** *ф.* Хәсрәтле итү, кайгы-борчу китерү. *Ләкин таба алмавы аны борчуга сала, хәсрәтләндерә.* М.Хәсәнов. *Бу сорау яшьләрнең үзләрен генә түгел, беренче чиратта аларның әти-әниләрен, якыннарын да хәсрәтләндерә.* Татарстан яшьләре

**Хәсрәтләндереп бетерү** Тәмам хәсрәтләндерү, бик нык хәсрәтләндерү

**Хәсрәтләндереп тору** Әледән-әле яки хәзерге моментта хәсрәтләндерү. *Анысы татар зыялыларын, укымышлыларын дистәләрчә еллардан бирле борчып, хәсрәтләндереп торган мәсьәләгә – Буби мәдрәсәсе тарихына багышланган иде.* Сөембикә

**ХӘСРӘТЛӘНҮ** *ф.* Борчылу, кайгыру, пошыну. *«Бу яртылаш җимерек өйдә яшәп буламы соң?» – дип хәсрәтләнде бугай.* Н.Дәүли. *Баксаң, ул чын йөрәктән бала өчен хәсрәтләнә икән лә!* М.Маликова

**Хәсрәтләнә башлау** Хәсрәтләнергә тотыну. *Шулай да, Гыйльметдин үз*

*телэгенә ирешүенә шикләнми, «берәр җае чыгар әле» ди, аның өчен хәсрәтләнә башлаган кызны тынычландырып.* Ф.Әмәк. *«Син әле кайчаннан бирле башкалар өчен хәсрәтләнә башладың?» – дип шукланырга маташты Әсфәндияр.* Җ.Рәхимов

**Хәсрәтләнеп алу** Кыска бер вакыт хәсрәтләнү. *Сүз уңаенда Исмәгыйль абзый өчен бераз хәсрәтләнеп тә алдылар.* Ф.Яхин

**Хәсрәтләнеп бетү** Бик нык хәсрәтләнү. *Кызын уйлый-уйлый хәсрәтләнеп бетте инде ул.* Р.Вәлиева

**Хәсрәтләнеп йөрү** Озак вакыт хәсрәтләнү; гел, һәрвакыт хәсрәтләнү. *Баксаң-күрсәң, бөтенләй юк өчен хәсрәтләнеп йөрисең икән, Өлфәт!* В.Нуруллин. *Гөлнисаны уйлап хәсрәтләнеп йөрмә.* Л.-Х.Таналин

**Хәсрәтләнеп кую** Бераз хәсрәтләнү; алдан ук хәсрәтләнү. *Алдан хәсрәтләнеп куйма әле.* Сөембикә. *18 яшькә хәтле әллә никадәр гомер бар әле, алдан ук хәсрәтләнеп куймыйм, дип тынычландырдым үземне.* Туганайлар

**Хәсрәтләнеп тору** Озак, һәрвакыт, даими рәвештә яки хәзерге моментта хәсрәтләнү. *Әйе, үзебез ана яки ата булмыйча торып, аларның балалары өчен ут йотып, ул-бу була күрмәсен дип һәр адымын күзәтеп, авырып китсәләр – төннәр йокламыйча хәсрәтләнеп торуының сәбәбен аңлап җиткермибез шул.* Ф.Тарханова

**Хәсрәтләнеп яту** *сөйл. к.* **хәсрәтләнеп тору**. *Институт тәмамлаган малайлары өчен дә хәсрәтләнеп ятмасыннар әле.* М.Миншин

**ХӘСРӘТЛЕ** *с.* 1) Хәсрәте, кайгысы, авыр уйлары булган, бәхетсезлеккә төшкән. *Үлем түшәгендә яткан, болай да нишләргә белмәгән хәсрәтле кешеләрне мәкерле тырнакларына эләктерергә йөрүче козгыннар янәшәбездә икән бит!* Д.Гыйсметдин. *Хәсрәтле хатын буылды, ул тешен кысты, чытырдатып күзләрен йомды.* Р.Камал

2) Хәсрәт, кайгы тулы, үтә борчулы (вакыт тур.). *Берәүгә әйтмәсә дә, ана күңелендә җылы бер өмет бар иде: инде шундый хәсрәтле көннәрендә улы, килен белән кайтып төшеп, аны куандыра алмасмы, дип уйлый иде.* А.Гыйләҗев. *Ананың хәсрәтле елы, аңа да сердәш булырсың.* Р.Мулланурова

3) Эчке авыр хисләрне, хәсрәтне, газапларны чагылдыра торган; бик моңсу, сагышлы, кайгылы. *Бу сүзләрне Мансур бик тирән хәсрәтле тавыш белән әйтте.* Г.Әпсәләмов. – *Әйдәле, Сәрвәр, әйдәле, Сәрвәр, мин сиңа өй салдым бит, барып кара инде, дип, миңа кат-кат әйтәсең, имеш, – дип көрсенде яңагына таянып утырган хуҗабикә, хәсрәтле күзләрен иренә төбәп.* З.Мурсиев

**ХӘСРӘТЛЕЛЕК** *и.* Хәсрәтле, борчулы, кайгылы булу хәле. *Район яисә республика вакытлы матбугатында кечкенә генә бер шигыреңнеңме, мәкаләңнеңме басылып чыкканын көтүләрнең рәхәтлеге, хәсрәтлелеге, ләззәтлелеге дисеңме!..* Шәһри Казан

**ХӘСТӘР** *и. фар.* Берәр нәрсә эшләргә җыенганда алдан күрелә торган әзерлек; билгеле бер вакыйга алдыннан яки билгеле бер вакыт җитү белән башкарыла торган һәртөрле әзерлек чаралары; мәшәкать. *Борчуларның шундый кайнап торган бер мәлендә туй хәстәре башланды.* Г.Бәширов. *Гали Даутович шуңа бик куанып-канатланып, ниһаять, безне дә орышырга түгел, мактарга килэләр, дип, кунакларны лаеклы каршылау хәстәре белән мәшгуль иде.* В.Нуруллин

◊ **Хәстәренә керешү** *к.* **хәстәренә керү.** *Кавидан курку башларыннан чыкмаса да, хәстәренә керешкәч, уйлары каядыр китеп юк булды.* З.Зәйнуллин. *Мин юктан файдаланып өйләнергә җыенуын да ишеткәч, «ятып калганчы, атып кал» дип, Хәйдәрне тиз арада үзенеке итү хәстәренә керешкән.* Ф.Тарханова. **Хәстәренә керү** Берәр нәрсә турында алдан кайгырта башлау. *Әти, кайткач ук хәстәренә керәм, әлбәттә, булышырмын, дип ышандыра.* А.Хәсәнов. *«Үзенә пар эзлидер, нәсел үрчетү хәстәренә кергәндер», – дип юрадык.* Ә.Моталлапов. **Хәстәрен күрү** Нәрсәгә дә булса алдан әзерләнү; нәрсәне дә булса алдан кайгыртып, әзерләп кую. *Рәт белгәннәре үзләре дә буш кул селкеп йөрмиләр, алдан ук хәстәрен күреп куйганнар, шулай җыйнаулашып мәш киләбез, иртә таңнан ризык-мазарын төйнәштереп көймәләргә төяләбез дә Иделгә, Казан диңгезен чуарлаган бәләкәй яшел утрауларга кереп китәбез.* А.Гыйләҗев. *Дөнья хәлен белеп булмый, хәстәрен алдан күреп танышa торабыз.* К.Кәримов

**ХӘСТӘРЛӘНҮ** *ф. сөйл.* Нәрсәгә дә булса әзерләнү, алдан хәстәрен күрү. *Инде кояш бераз гына кичкә авышытымы, китә киенү-ясану, кичке су китерүләргә хәстәрләнү.* Г.Бәширов

**ХӘСТӘРЛӘ́Ү** *ф.* 1) Берәр нәрсәне кору, җыештыру, көйләп җибәрү һ.б.ш. өчен кирәк булган эшләрне эшләү. *Ул җитез-җитез атлап, мәтрүшкәле чәй хәстәрләргә кереште.* Г.Әдһәмова. *Тиз-тиз кузгалып, ул кунакларга өстәл хәстәрләде, ачык йөз белән хөрмәт күрсәтте.* З.Мурсиев. *Мунча хәстәрләп, мунча керү түгел, чишенеп тә торасы килмәгән көннәрем күп була.* Ф.Садриев

2) Әзерләү; алдан ук әзерләп, барлап, рәтләп, әзер хәлгә китереп кую. *Ядкарь буяу пумалалары табып куя, Гамил белән Таймас олифа алып кайталар, Рәуф үзе шпангоутларны почмактан беркетә торган тимерләр хәстәрли.* А.Тимергалин. --- *Радмирның ике кызына ике шәһәрдә хәстәрләгән фатиры һәм ике машинасы Фәзилә өчен чүп кенә – фил янындагы чебен генә иде.* Г.Мирһади

3) *диал.* Карау, тәрбияләү. *«Чүлдә агачлар да, аларның җимешләре дә сабый баланы карагандай хәстәрләп үстерелә», – диде, әллә көнләшеп, әллә горурланып.* Шәһри Казан. *Без – синең атаң-анаң, сине тудырдык, сөеп, хәстәрләп үстердек; син аякта йөри башлап, телең чыгып «әни, әти» диган сүзеңне ишетеп, бик сөенештек ---.* Туганайлар

**Хәстәрләп алу** Тиз генә, кыска вакыт аралыгында хәстәрләү. *Ереләнеп киткән Троцкий урындыгына сөялеп атынырга ук керешә, аягын аякка атландырып, куллары белән хром итек кунычын хәстәрләп ала.* *Минем эш эшләнгән, янәсе.* Р.Мөхәммәдиев. *Тиз генә хәстәрләп алган шушы табын аңа гаилә, дөресрәге, булачак гаилә тормышларының кечкенә генә бер мизгелен күзалларга мөмкинлек бирә шикелле.* Ә.Сафиуллин

**Хәстәрләп бетерү** Барысын да хәстәрләү, тулысынча хәстәрләү. *Фатыйма белән Роза табынны хәстәрләп бетергәннәр иде.* Р.Гаязетдин. *Барысын берьюлы хәстәрләп бетерсәң, үләсе генә кала ич.* Р.Мулланурова

**Хәстәрләп җибәрү** Бераз, берникадәр хәстәрләү. *Менә эшкә башлап, өс-башларыңны хәстәрләп җибәрсәң, өйләндерәбез үзеңне.* Ш.Маннур

**Хәстәрләп йөрү** Күптәннән бирле хәстәрләү; даими, озак вакыт хәстәрләү. *Ул, Киевтан Венгриягә ял итәргә генә качмый, башта Венгрия, аннан соң Польша корольләре белән татарга каршы коалиция оештыру ягын хәстәрләп йөргән булган.* И.Хуҗин. *Нәфисә Хә-*

*лимнең яңа бура хәстәрләп йөрүенә бер куанды, бер борчылды.* Г.Гыйльманов

**Хәстәрләп карау** Хәстәрләргә омтылу, хәстәрләргә тырышу. *Ерганакчокыр тирәләрен хәстәрләп караганнар, ярларда вак-төяк чаукалыклар калкынган.* А.Гыйләҗев

**Хәстәрләп кылу** Электән үк хәстәрләү. *Күптән карап торган, хәстәрләп килгән чыршысы да бар.* Р.Мөхәммәдиев

**Хәстәрләп кую** Алдан ук хәстәрләү. *Хәстәрләп куйган чыбык-чабыктан учак үрләтеп җибәрделәр.* А.Тимергалин

**Хәстәрләп тору** Хәзер хәстәрләү; даими, гел хәстәрләү. *Әллә соң барысына төкереп, кайтып, аш хәстәрләп торыргамы?..* М.Хәбибуллин. *Нуриевның баш очына куелган тере чәчәк бәйләмнәре, гөлләргә ишарәләп сорап куйдым: – Боларны кем китерә, кем хәстәрләп тора шулай?* Р.Мөхәммәдиев

**Хәстәрләп чыгу** Берсен дә калдырмыйча, барысын да хәстәрләү. *Бүлмә буенча йөренеп, үз әйберләрен хәстәрләп чыкты.* Н.Гариф

**Хәстәрли башлау** Хәстәрләргә керешү. *Әйләнеп керде һәм, күңелле генә сөйләнеп, кунаклар өчен чуклы сөлге, алмаш киемнәр салынган төенчек хәстәрли башлады.* Р.Низамиев. *Ул йөгереп барып чәй куйды, өстәл хәстәрли башлады.* З.Хөснияр

**Хәстәрли тору** Әле хәзерге вакытта хәстәрләү; берәр хәл булганчы хәстәрләү. *«Әй бала, бала, урам буйлап җил куып йөргәнче, йорт-җирне караштырып, утынын-суын хәстәрли торсаңчы!» – диган шелтәле сүзләрне ишеткәндәй булды ул.* Л.Хәмидуллин. *Син, бар, үз эшеңне хәстәрли тор, ә без Фаһман абый белән станокны маташтырып карыйк.* З.Мурсиев

**ХӘСТӘРЛЕ** *с.* Алдан кайгыртучан, хуҗалыклы. *Шуның өстенә хәстәрле Шакирҗан юбилярга бүләккә япон халаты – киң итәкле, кыска җиңле, сары чәчәкле матур кимоно алып куйган икән.* С.Сабиров. *Шуңамы, әбиләр, хәстәрле апалар бу айда көлтә-көлтә үлән киптерәләр, чабынырга себеркесен җыялар.* Н.Кәримова

**ХӘСТӘРЛЕК** *и.* Хәстәрләү эшләре, төрле хәстәрләр. *Тизрәк араны җайлап, туйга хәстәрлек башларга иде бит.* Н.Гыйматдинова. *Һәр елның сентябрендә Литфонд идарәсенә үтенеч хатларын һәм шуңа өстәлгән документларны илтеп тапшыру өчен, ел башыннан ук хәстәрлек эшенә керешә идем.* Г.Бәйрәмова

◊ **Хәстәрлегенә керешү** *к.* **хәстәренә керү**. *Туй хәстәрлегенә керешкән вакытта ятакка калды ул.* Шәһри Казан. **Хәстәрлек күрү** *к.* **хәстәрен күрү**. *Кар калынайганчы, киселгән бүрәнәләрне авылга кайтару хәстәрлеген күрергә кирәк иде.* Г.Гыйльманов. *Алдан хәстәрлек күрмәве – сумка алмавы өчен үзен сүгә-сүгә, бер кочак китап күтәреп кайтып килеше иде.* Г.Әдһәмова

**ХӘСТӘРЛЕКЛЕ** *и. сөйл. к.* **хәстәрле**. *Инспектор Фазылханов шундый, ә синең өчен мин – Таймас, игелекле һәм хәстәрлекле кеше, ул яктан борчылма.* З.Мурсиев. *Өлкән шагыйрь аларның һәммәсенә хәерхаһ булды, иҗатларына игътибарлы, үзләренә аталарча хәстәрлекле булды, алтындай вакытын да, көчен-энергиясен дә кызганмады.* Р.Миңнуллин

**ХӘСТӘРЛЕЛЕК** *и.* Хәстәрле булу сыйфаты. *Әмма дә үз йорты эчендә хәстәрлелеге, ире белән балаларын һәрьяклап кайгырта белүе, аларның кайсысына кайчан ни-нәрсәләр кирәк буласын, --- кайсысыныңниләр итеп күңелен күрәселәрен дисеңме, бу җәһәтләрдән инде Мәфтуха түтиең – авыз тутырып әйтерлек академик.* М.Рафиков. *Аның сабырлыгы, хәстәрлелеге акылдан язар чиккә җиткән ананы акрынлап тормышка кайтара, һәм көннәрдән бер көнне ул дөньяга күзләрен ача.* Кызыл таң

**ХӘТ** *и. гар.* Чик. *Аллаһ тарафыннан куелган чикләрне (хәтне) бозу иң зур гөнаһлардан санала.* Казан утлары. *Чөнки әйтәсе инде әйтелгән, язасы да хәттин күп язылган.* З.Мурсиев. *Агай боларның барысыннан да канәгатьлек тоеп, чын хуҗаларча сөйләнә-сөйләнә мич ягып йөргәндә: – Хәттин зур кайгың бармы соң, олан?* Н.Гыйматдинова

◊ **Хәттин ашу** Чамадан узу, чиксез күп булу. *Гомумән, Ансарда хыяллар җитәрлек инде, хәттин ашкан.* Р.Фәизов. *Аның бөтен яшәешен җентекләү – кирәксез эш, аерым кешеләрнең кызыксынучанлыгы хәттин ашарга мөмкин – аңа һич тә юл куярга ярамый...* Т.Әйди. **Хәттин узу** *к.* **хәттин ашу**. *Кәләпүш тә бик тузган, Бүрек тә хәттин узган.* Г.Камал

**ХӘТӘР** *с. гар.* **1.** 1) Куркыныч, начар, яман, хәвефле. *Эшнең хәтәр борылыш алуын Фәннур сиземләп өлгергән иде инде.* А.Гыймадиев. *Гүя мин нидидер хәтәр җинаять эшләгәнмен дә, алар мине хөкем итәләр.* А.Вергазов

2) Бик усал, кызу, дуамал; башкалар куркып тора торган. *Рәис хәтәр кеше иде, элек райкомда эшләгәндә гаепкыегы чыгып, аны иң фәкыйрь колхозларның берсенә баш итеп җибәргәннәр.* А.Гыйләҗев. *Синең ише хәтәр кеше белән бергә яшәү – үзе бер юаныч, үзе зур дан.* В.Имамов

**2.** *и. мәгъ.* 1) Куркыныч, бәла-каза, бәхетсезлек. *Хәтәр, хыянәт, фаҗига сине монда атлаган саен көтеп тора.* А.Хәсәнов. *Урманнан чыгарга ярамый: анда үлем көтә, хәтәр сагалап тора.* К.Кәримов

2) Бик усал, кызу, куркыныч, дуамал кеше. *Иптәш начальник, аеруча хәтәрләрне алып килдек.* И.Салахов. *– Карабрак йөр, бабай, – диде ир. – Ул хәтәрләр сытып китәргә дә күп алмаслар.* Р.Батулла

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Куркыныч рәвештә, хәвефле итеп. *Күпме булса дәртең, шулкадәрле Хәтәр оча дошман уклары.* И.Сабиров. *Мылтык тавышлары, этләрнең хәтәр өрүе, исерекләрнең ачы сүгенүе бергә җыелып, Сайдәнең аңзиһенен томалап алды.* Г.Гыйльманов

2) Бик нык, бик каты, хәйран, шактый, сизелерлек итеп. *Һе, тимер челтәрле коймалар белән дә әйләндереп алгач, ихата дигәнең хәтәр бөтенәеп, җыйнакланып киткән икән бит, күз генә тимәсен.* В.Имамов. *Тартуын тартты Наил, тик соңыннан үзе дә үкенде: хәтәр авырттырды бугай – ыңгырашып өлгермәсә дә, малайның күзләреннән яшь атылып чыкты.* К.Кәримов

3) Бик, шактый дәрәҗәдә, искиткеч. *Уенда каймак та, эремчек тә калмады, тыштан хәтәр затлы күренгән табылдык бар булмышын биләде.* А.Әхмәтгалиева. *– И-и, кызым, хәтәр тәмле икән бит бу! – диде ул, бер-бер артлы юа үсентеләрен каба-каба.* А.Фәләх

4) Шәп итеп, яхшылап, кәттә, соклanырлык дәрәҗәдә. *Шулай да үзе бик таза, җәй буе көтү көтә, чыбыркыны бик хәтәр шартлата.* Г.Бәширов. *Карап торуга болай ук хәтәр биш торган кеше дип уйламассың үзегезне.* З.Хәким

5) Эре кыяфәт чыгарып, башкалардан өстен булырга тырышып. *Базык гәүдәле, трикосына буяу таплары төшкән егерме биш яшьләрдәге егет барысыннан да хәтәр кылана.* А.Вергазов. *Чум-чум атлап хәтәр йөри идек, Кызган кабак төше чертләтеп.* И.Гыйләҗев

**4.** *хәб. мәгъ.* Яман, начар, куркыныч, яхшы түгел. *Олы кешегә кинәт җил кагылса, хәтәр!* А.Гыйләҗев. *Назимовка бик авыр иде, ләкин бәхәскә керү дә хәтәр: тавышка кешеләр килүе бар.* Г.Әпсәләмов

**ХӘТӘРЛЕК** *и.* 1) Бәла-каза, бәхетсезлек, куркыныч хәл, яманлык. *Мондый хәтәрлекне илгә түгел, Кан дошманыма да теләмәм.* Ф.Гыйззәтуллина. *Менә шушы хәтәрлекләрдән сак бул, туганкай!* Р.Низамиев

2) Хәтәр булу сыйфаты, куркыныч булу дәрәҗәсе. *Хәлнең хәтәрлеген аңлап җиткермәү*

**ХӘТЕМ** *и. гар.* 1) Хатның азагында имза урынына басыла торган тамга

2) Коръәнне, багышлап, ахырына кадәр укып чыгу, Коръән чыгу. *Әбелмәних майламаган арба шыгырдавына охшаган тавыш белән мәетләр рухына хәтем укый башлады.* Г.Әпсәләмов. *Бөтен муллаларны җыеп хәтем укыттым.* Р.Әмирханова // *сөйл.* Гомумән Коръәннән берничә аять уку. *Ул кара конверт килгән йортка кереп хәтем укый, гүр садакасы ала.* Һ.Такташ. *--- биш-алты кеше чакырып кына хәтем укыталар.* Милли-мәдәни мирас

3) Коръән аятьләре укыла торган сый мәҗлесе; Коръән ашы. *Шул уңай белән янәшә-тирәдәге муллаларны, хәлфә, шәкертләрне хәтемгә чакырдым.* Т.Гыйззәт. *Карача вәзирнең уллары кайгысыннан җиңеләер хәлгә килгәнен күреп, аның белән Күчем хан үзе дә, сәед-шәехләр дә сөйләшеп карады, берничә тапкыр Коръән укытып, хәтем ашлары уздырдылар.* Ф.Бәйрәмова

◊ **Хәтем әйтү** Коръәнне тулысынча укып чыгып, багышлау. *Ул да Тукай мәрхүмгә багышлап мәчетләрдә хәтем әйтте.* Г.Исхакый. **Хәтем чыгу** *к.* **хәтем әйтү**. *Әкрәм кари әнә шулай хәтем чыга башлады.* М.Галәү

**ХӘТЕ́М ИТҮ** *ф. к.* **хәтем кылу**. *Коръән хәтем иткән абыстай, йомшак тавышы белән нәсыйхәт һәм үгетләрен әйтеп, тормышның барлыгынабулганына, килгәненә-киткәненә сабыр кылырга кирәклеген аңлатты.* Ф.Яхин. *Җиде атнада җиде мәртәбә Коръән хәтем итте.* Сөембикә

**ХӘТЕ́М КЫЛУ** *ф.* Коръәнне тулысынча укып чыгып, багышлау. *Үтәмеш әтисенең рухына хәтем кылып кала.* Р.Зәйдулла

**ХӘТЕР** *и. гар.* Элек булган вакыйгалар, кичерешләр турындагы мәгълүматны, тәэсирләрне саклый һәм яңарта алу сәләте; ис, зиһен. *Волга-Дон каналында эшләгән, сугышта катнашып, Курск дугасында каты яраланган кешенең сөйләр нәрсәләре байтак, аның хәтере искиткеч яхшы, ул әллә никадәр кешеләрнең исем-фамилияләрен, холык-табигатьләрен, тотышларын хәтерли.* А.Гыйләҗев. *Аның хәтер байлыгына, зиһененең зирәклегенә сокланмаган кеше калмагандыр, мөгаен.* Г.Галиева

◊ **Хәтергә алу** 1) Искә төшерү, телгә алу, игътибарга алу. *Өен – старостага, мунча бурасын – хәзрәткә, каралтысын Гаделша байга биреп, төрлечә алдау юлы белән төрмәдән котылып калуына кадәр хәтергә алдылар.* М.Хәсәнов; 2) Хәтерләү, истә калдыру. *Узган-барган һәр катерны күзәтү, хәтергә алу безнең командалар вазифасына керми.* С.Сабиров. **Хәтергә беркетү** Онытмаслык итеп истә калдыру. *Аңсыз рәвештә ясалган бертөрле теләсә нинди хәрәкәт, мисалга, шул ук сагыз чәйнәү, нәрсәне дә булса хәтергә беркетеп калдырырга комачаулый.* Шәһри Казан. **Хәтергә бикләү** 1) Истә калдыру. *Килде-китте исем түгел икән. Хәтергә бикләсәң дә ярый.* Г.Әпсәләмов. *Киләсе очрашуда аның белән генә сөйләшәсе темаларны хәтергә бикләп барам.* Идел; 2) Ятлау. *Күренеп торган талантның да, сәләтең дә булмаган хәлдә, ничек инде шундый җаваплы эшкә ризалык бирергә мөмкин, дип каршы төшкәч, ул, җавап биреп: «Пьесаның характерына һәм идеясенә төшенә алсаң, үзең башкарачак образның сүзләрен аңлап-төшенеп хәтергә бикләсәң – шул җитә», – диде.* З.Тинчурина. **Хәтергә дә кертмәү (китермәү)** Берәр нәрсә турында гомумән уйламау, искә дә алмау. *Шунлыктан, тетрәү көн саен дәвам итсә дә, доктор дип әйткән кешене хәтеремә дә кертмидер идем.* Г.Тукай. *Тиз генә китеп барырмын, дип хәтереңә дә китермә ичмасам.* Ф.Әмирхан. **Хәтергә дә килмәү** Искә төшмәү. *Куанычымнан анысы хәтеремә дә килмәгән.* Ш.Бабич. *Юк, хәзрәт, минем алдан әзерләп куярга һичбер хәтеремә дә килмәгән.* Г.Камал. **Хәтергә килү** 1) Искә төшү, хәтерләнү. *Рәбигалар искә төшкәч, кичәге вакыйга хәтергә килде.* Г.Рәхим. *Инде генә онытылды дисең, яңадан хәтергә килә дә күңелне телгәли башлый.* Р.Миңнуллин; 2) Уйга килү, башка килү. *Кул чабу һичкемнең хәтеренә килмәде, музыканың, җырның туктаганын, музыкантлар чыгып китеп, сәхнә буш калгач кына аңлый алдылар.* Г.Ибраһимов. **Хәтергә китерү** Искә төшерү, уйлау. *Мортазин Рәйсә ханымның сүзләрен хәтергә китерде.* В.Имамов. *Бу – өзелеп-өзелеп туган авылыңны сагыну, карга оялаган карт тупылларны искә төшерү, кырда үскән бодай, арышны, зәңгәр чәчәкле җитен басуын хәтергә китереп, эчтән генә үкереп-үкереп елау...* Р.Сибат. **Хәтергә салу** Онытылмаслык итеп күңелгә беркетү. *Ничек кенә булмасын, моны хәтергә салып куйыйк, гомер булса – күрербез: бу Бибиковка нәрсә булыр икән?* З.Мурсиев. *Секунд арасында автобус номерын, ишегенә сугылган түгәрәк адрес-билгесен хәтергә салам.* Н.Гариф. **Хәтергә сеңү** Онытылмаслык булып күңелдә, истә калу. *Салих әфәндедәнең бөтен әйткәннәрен аңлавы җиңел иде, һәр әйткәне ничектер үзеннән-үзе күңелгә кереп, хәтергә сеңеп бара иде.* Ә.Еники. *Бермәлне шулай укудан кайтып килгәндә, күпергә җитәрәк бер картны очратып сөйләшкәнем, нишләптер, хәтергә сеңеп калган.* К.Миңлебаев. **Хәтергә төшерү** Искә төшерү. *Мин моннан ике ел булып үткән матур күренешләрне кайта-кайта хәтергә төшереп утырам.* Б.Рәхимова. *Хәер, авылдан читтә яшәгәч, һәркемне дә хәтергә төшерергә җае да чыкмагандыр.* М.Хуҗин. **Хәтергә төшү** *к.* **хәтергә килү**. *Кайдадыр укыган акыллы сүз хәтергә төште.* А.Гыйләҗев. *Татарның тагын бер акыллы мәкале хәтергә төште: «Син дә мулла, мин дә мулла, атка печән кем сала?»* Р.Вәлиев. **Хәтердә калдыру** *к.* **хәтергә беркетү**. *Тик, төсләргә алданып, чәчәкләрнең исемнәрен генә хәтердә калдырып булмый.* Г.Бәйрәмова. *Барысын да ничек хәтердә калдырып бетерәсең, ди!* Г.Гыйльманов. **Хәтердә калу** Хәтерләнү, истә булу. *Көне-сәгате хәтердә калмаган, ялдан кайткан чагы булгандыр, дип чамалыйм.* А.Гыйләҗев. *Хәтердә калганы шул: тәмәке тартмаска, аракы эчмәскә, гел кул юып кына торырга кирәк икән.* Г.Афзал. **Хәтердә саклау** Истә тоту, онытмау. *Бары тик үткәнне хәтердә саклап кала алган халык кына киләчәккә зур өмет баглый ала.* М.Хәбибуллин. *Гөлшат апа Зәйнашева белән без Казанда беренче тапкыр кайчанрак очрашканбыздыр, анысы хәтердә сакланмаган.* Ф.Яруллин. **Хәтердә тоту** 1) *к.* **хәтердә саклау**.

*Хәтта синең кайсы шигырең кайсы газетада яки журналда басылып чыкканга кадәр хәтердә тота.* Ф.Яруллин; 2) Игътибардан югалтмау, күздә тоту, исәптән чыгармау. *Шагыйрь күңеле үз халкының бөтен тарихын хәтердә тотып иҗат итә.* Р.Фәйзуллин. **Хәтердән чыгару** Оныту. *Тик шуны гына хәтердән чыгара күрмә, Зифа апай: камырны сөткә генә изәрсең.* Г.Ибраһимов. *Янәшәдәге өстәл читендә нәрсәдер язып утырган Иванов барлыгын бөтенләй искәрмәгәнмен, хәтердән чыгарганмын икән бит!* З.Зәйнуллин. **Хәтердән чыгу** Онытылу. *Тилмереп караган күзләре дә, соңгы сүзләре дә нишләптер онытылмый, хәтердән чыкмый.* Ф.Баттал. *Әмма ул яман төш һич тә хәтердән чыгарлык түгел иде инде.* М.Вәлиев. **Хәтер дәфтәре** Зиһен, аң, күңел. *Артист халкының күзе очлы: театрда ике-өч тапкыр күренгән тамашачыны хәтер дәфтәренә теркәп тә куя.* Н.Гыйматдинова. *Бу илдә узган чакрымнарның һәр тукталышы, онытылмаслык хатирә булып, хәтер дәфтәрендә теркәлә тора.* Г.Шәйхи. **Хәтере калыр** Берәр нәрсә турында сөйләгәндә, аның үз ишләренә, шундыйрак башка әйберләргә караганда кайтышрак, кечкенәрәк, ябыграк, начаррак, ямьсезрәк һ.б.ш. булуын күреп, кимсетү, дәрәҗәсен төшерү төсмере белән әйтелә. *Ресторан димәсәң – хәтере калыр, бер өйнең адәм рәтенә китерелгән подвалы инде.* В.Нуруллин. *Эт димәсәң – хәтере калыр, бияләй хәтле генә чәңгелдек бер нәрсә инде шунда.* И.Хәйруллин. **Хәтерен күрү** *к.* **хәтерен табу**. *Гүяки аны дөнья йөзендә сөюче, гүяки аның хәтерен күрүче юк.* Ф.Яхин. **Хәтерен табу** Кемнең дә булса күңелен күрү, аңа ярарлык эш эшләү, ярарга тырышу. *Мондый мәгърифәт иясенә хөрмәт күрсәтеп, хәтерен табудан башка чара юк, дип уйлап куйдым.* К.Насыйри. *Җиреңнең күңелен, хәтерен табарга тырыш, ашлама бир, әйбәтләп эшкәрт, шунда гына җир дә синең күңеләңне күрер: мул уңыш бирер ---.* Казан утлары. **Хәтерең бар булсын (булгыры)** Нәрсәне дә булса онытып, вакытында искә төшерә алмаганда әйтелә. *[Көмеш:] Әй, хәтерең бар булсын, чәйгә керегез, чәйгә! Куанычым белән онытып китәрмен икән.* М.Фәйзи. – *Теге галимнәрдән соң торган Нәкыйп ни дип җырлый торган иде әле? – Хәтерең бар булгыры...* Т.Гарипова. **Хәтер калдыру** Кемне дә булса рәнҗетү, кәефен җибәрү, үпкәләтү. *Шуңа күрә җавап бирергә ашыкмады: аның һич тә бу мөлаем, үз ыру-нәселен ихластан яраткан яңа дусларны рәнҗетәсе, хәтерләрен калдырасы килми иде.* М.Әмирханов. *Училищеда укыганда бер мөртәте, сукырдан сукыр туар инде ул, дип, бик нык хәтерне калдырган иде, күзле туган бит, ә!* К.Кәримов. **Хәтер калу** Кемгә дә булса үпкәләү, рәнҗү; күңелдә авыр тәэсир калу. *Шуннан соң әти, бик каты рәнҗеп, бик яман хәтере калган сыман, беркем белән дә сөйләшмичә, карасына батып йөри торган булды.* Г.Бәширов. *Хәдис, хәтере калган кыяфәттә артка чигенә-чигенә, ишек төбендәге юан аяклы тирәүсез утыргычка лап итеп утырды.* А.Вергазов. **Хәтер капчыгы** 1) Хәтер; күңел. *Ул барысын да күңеленә сеңдерә, хәтер капчыгына тутырып бара.* Р.Миңнуллин. *Кайчандыр, бик күп еллар узгач, күңелеңнең иң моңсуланган бер чагында, дөньядан күңелең кайткан, кешеләргә, дусларыңа, сөеклеңә ышанычыңны җуйган бер мизгелдә шуларны хәтер капчыгыңнан тартып чыгарырсың.* Х.Ширмән; 2) Хәтере бик яхшы булып, күп истәлекләрне күңелендә йөртә, бик күп мәгълүматны исендә тота торган кеше. *«Хәзер, ниндидер бер датаны әйтсәләр, шул көнне миңа бәйле нинди хәлләр булса, шулар күз алдыма килә дә баса», – ди «хәтер капчыгы»на әйләнгән ханым.* Ватаным Татарстан. **Хәтер кырылу** *к.* **хәтер калу**. – *Монда соң кәләпүш кайдан килсен, – дип, үзенең дә хәтере кырылгандай, сөйләнә-сөйләнә чыкты әтисе.* Ф.Хөсни. *Әнә бит ул картлар күңеле нинди! Юктан да хәтерләре кырылучан.* Х.Кашапов. **Хәтер сандыгы** 1) *к.* **хәтер капчыгы**. *Әсәрләремне беркайчан да яттан белмәдем, әмма әлеге артистларның хәтер сандыгына унар хикәям сыйган.* Ватаным Татарстан. *Рәмзия Гайфуллинаның хәтер сандыгында тормышында булган бик күп истәлекле вакыйгалар саклана.* Кызыл таң; 2) Сәнгать, әдәбият, тарих һ.б.ш.га караган күптөрле мәгълүматлар, чыганаклар саклана торган фонд, база, урын. *Аларның күңелләренә уелып калганнары бүген дә Татарстан радиосының хәтер сандыгы – алтын фондында саклана һәм, даими хәрәкәткә китерелеп, эфирдан яңгырап тора.* Р.Фәйзуллин. *Музейларны хәтер сандыгы дип юкка гына әйтмиләр шул.* Мәйдан. **Хәтер өчен (генә)** Кемнең дә булса күңеле булсын өчен; үпкәләтмәс, рәнҗетмәс, күңелен табу өчен. *Диләфрүз аңа: «Шүрәле»гә бер артык билетым бар, барырга теләмисезме?» – дигәч, ул аның хәтере өчен генә риза булды һәм, театрга барган чагында гына: «Ни өчен Диләфрүзнең бер билеты артып калган?» – дип уйлады.* Г.Әпсәләмов. *Клара, карт кешенең хәтере өчен генә аны тыңлаштырса да, барыбер үзенчә уйлый иде.* Ә.Еники. **Хәтер саклау** Үпкәләтмәскә, күңеленә тимәскә, кәефен бозмаска тырышу. *Бәхәсләшкән чагында артык нечкәләп тормас, хәтер дә сакламас, йомшаклык та күрсәтмәс – хакыйкатьне ярыр да салыр.* Г.Әпсәләмов. *Үз теләгемә каршы килеп булса да, көне буе синең хәтерне саклап йөрим, җитәр!* А.Гыйләҗев

**ХӘТЕРДӘН** *рәв. сөйл.* Яттан, укымыйча, күңелдән. *Шуңа күрә теге-бу илнең халкы, экономикасы турындагы мәгълүматларны хәтердән сөйләү бик авыр.* М.Мәһдиев. *«Кара икмәк», «Кешегә нәрсә җитми» кебек шигырьләрен хәтердән сөйләр дә: «Эх, шушы баланы бер генә күреп, аркаларыннан сөйсәң иде!» – дип куяр иде.* Безнең мирас

**ХӘТЕРЛӘТҮ** *ф.* 1) Искә төшерү өчен этәргеч булу. *Бу җыр иге-чиге булмаган далаларны хәтерләтте, кара урманнарны күз алдына китереп бастырды, кара болытлы көзге көннәрне, давыллы диңгезләрне искә төшерде.* Г.Кутуй. *Буфет эченә кадаклаган җиз калай Хөршидәттәйгә тормышның әнә шул сәхифәләрен хәтерләтә иде.* А.Тимергалин

2) Кемгә яки нәрсәгә дә булса охшаш кебек күренү, тоелу. *Рәмзия нәрсәсе белән Гайнияне хәтерләтә соң?* Н.Әхмәдиев. *Агачлардагы яфракларны, салмак кына искән җилне, колакны иркәләгән илаһи музыкаль авазлар үксеп-үксеп адәм баласы елаганны хәтерләтә иде.* З.Мәхмүди

**Хәтерләтә башлау** Хәтерләтергә тотыну. – *Юк, бозмаганнар... – диде, хәзер инде пәйгамбәрне хәтерләтә башлаган окулист.* М.Хәсәнов. *Ул күбесенчә яралы кошчык өстенә ташланырга әзерләнгән ерткыч мәче карашын хәтерләтә башлады.* В.Имамов

**Хәтерләтә төшү** Бераз хәтерләтү. *Беренче карауга бу – татар халкының узган чорында яшәгән руханиларның биографиясенә бәйләнешле материалларны туплаган дини биографик җыел-*

*маны хәтерләтә төшә.* М.Госманов. *Бишенче вариантында ул инде сурәтләү чаралары белән тулыланып, Кол Харисның хикәяләү алымнары белән бизәлеп, детектив жанр кануннары белән тасвирланган фильмны хәтерләтә төшә иде.* К.Кәримов

**Хәтерләтеп җибәрү** Бераз, беркадәр хәтерләтү. *Аларның табыны бәхетле гаиләнең кайчандыр менә шулай барысы бергәләп, гөрләшеп утырган чакларын хәтерләтеп җибәрде.* Ә.Еники. *Ун катлы өйнең тәрәзәләрендә берәмберәм утлар кабына башлады, әллә ничек шунда өй шахмат өстәлен хәтерләтеп җибәрде.* М.Хәбибуллина

**Хәтерләтеп кую** Бераз вакытка хәтерләтү. *Быел да авылга читтән кайтучылар күп булып чыкты, Караболак элеккеге бәхетле чакларын хәтерләтеп куйды.* Ф.Бәйрәмова. *Ул ара-тирә Мәрьям әби кәҗәсенең ачыкканда, сусаганда кычкырган тавышын да хәтерләтеп куйгалый.* Ә.Гаффар

**Хәтерләтеп тору** Әле, хәзер хәтерләтү; һәрвакыт, бертуктаусыз хәтерләтү. *Монда да, ишегалдындагыча, бөтен нәрсә туган илне хәтерләтеп тора иде.* М.Галәү. *Нигә өянке бер якка кәкрәеп, теләнеп йөрүче хәерчене хәтерләтеп тора?* М.Яһудин

**ХӘТЕРЛӘҮ** *ф.* 1) Хәтердә саклау, онытмау, истә тоту. *Азат белән арабыз бозылган чакны хәтерләмим, бәхәсләшү, ярышу-узышуларсыз түгел, билгеле, ләкин яшь әтәчләр кебек кыдрачланып сугышканыбыз булмады.* А.Тимергалин. *Яхшы хәтерли: җомга көнне кич кенә кайтып җитте алар.* З.Хөснияр

2) Искә төшерү. *Аннары үзенең бирегә ни өчен килүен хәтерләде дә дивар буенда тып-тын гына утырып торган бер ападан китапханәнең кайда икәнлеген сорады.* М.Вәлиев. *Тагын нәрсә булгандыр, калганын хәтерли алмады.* Л.Гыймадиева

**Хәтерләп алу** Бераз, берара хәтерләү. *Карт, киез җәйгән сәкегә ятып, картларга: – Кая, картлар, әйдәгез бераз җырлап җибәрегез, борынгы батырлар, үткәндәге бабайларның батырлыкларын хәтерләп алыйк! – диде.* Г.Гобәйдуллин. *Карчыкның чәчләре ак булса да, Вера аны алай ук олы булыр дип уйламаган иде, әмма, чәй эчкән арада, анысы бераз үзенең гомер юлларын хәтерләп алды.* З.Мурсиев

**Хәтерләп бетерү** Тулысынча, булганның барысын да хәтерләү. *Барысын да хәтерләп бетермим, исемдә калганнарын әйтим әле.* Г.Галиева. *Мин әнкәйләрнең кемгә нәрсә язганнарын инде хәтерләп бетерә алмыйм, әмма фронттан килгән хатлардагы юллар йөрәгемә мәңгегә уелып калдылар.* Г.Гыйльманов

**Хәтерләп калу** Онытмаслык итеп күңелгә беркетеп кую. *Ләкин алышыныбрак йөрүче бу сәер хатынның күзләрен яхшы хәтерләп калды ул: ничектер үз, якын, кадерле иде бу карашлар.* Г.Гыйльманов. *Балаларның җидесе дә шуны нык хәтерләп калырга тиешләр, аларның балаларының балалары да онытмаслык булсын.* К.Кәримов

**Хәтерләп кую** Кинәт, көтмәгәндә хәтерләү; тиз арада хәтерләү. *Мирсәет Бакуда калган гаиләсен – кызын, зәңгәр күзле Раузасын хәтерләп куйды.* Р.Мөхәммәдиев. *Кайчакта, оныгына карап, үзенең, улының балачагын хәтерләп куя.* Ф.Җамалетдинова

**Хәтерләп тору** Әле, хәзер хәтерләү; һәрвакыт хәтерләү, барысын да хәтерләү. *Фәһимә апа көзге каникулда кемнең нинди китап укыганын ничек хәтерләп торсын.* В.Нуруллин. *Теге дөньяны гел хәтерләп торырга кирәк.* Р.Зәйдулла

**Хәтерли башлау** Хәтерләргә тотыну. *Аннары инде, үсә төшкәч, мин аның курайда уйнавын да хәтерли башладым.* Ә.Еники. *Кеше уйга чума, ул хәтерли башлый, очы да, кырые да юк аның хәтеренең...* Г.Әпсәләмов

**ХӘТЕРЛЕ** *с.* Хәтере яхшы булган, онытмаучан, күп нәрсәне хәтерендә саклый торган, зиһенле. *Наиләне – тәҗрибәле, хәтерле һәм булдыклы референтны – генеральный директор Урал ягы шәһәрләренең берсенә алып китәргә җыенгач, Наилә кырыс һәм йомылган иренең иңенә кулын салды.* А.Гыйләҗев. *– Татар – бик мәрхәмәтле, бик хәтерле халык икән, бу – минем иң зур ачышым, – диде Татли.* М.Әмирханов

**ХӘТЛЕ** *бәйл.* **1.** 1) Юнәлеш килешендәге урын төшенчәсен белдергән исемнәр белән килеп, эш-хәрәкәтнең икенче бер чик ноктасын билгеләү өчен кулланыла; чаклы, тикле, кадәр. *Полк Казанга хәтле бер атналап барды.* И.Хуҗин. *«Барый Ләйсәнне өенә хәтле озатты микән?» – дип уйлады малай.* А.Гыймадиев

2) Берәр күренеш, эш-хәрәкәт һ.б.ш.ның телгә алынган башка бер вакыйгадан алда булуын белдерә. *Башкалар кебек чыгымлап йөрмәде, кергән көненнән алып сугыш чыкканчыга хәтле күмәк хуҗалыкта атлар карады.* З.Зәйнуллин. *Элек, эчүчелеккә каршы карар чыкканга хәтле, рәхәт иде: кайчан телисең, күпме телисең – рәхәтләнеп чөмер, беркем сиңа бер сүз әйтми иде.* В.Нуруллин

3) Юнәлеш килешендәге исемнәр белән килеп, «барысы да», «бөтенләе белән», «тулысынча» дигән мәгънәне белдерә. *Бөтен Германия буйлап тоталь мобилизация баруы, унбиш яшьтән алып ак сакаллы бабайларга хәтле барлык ирләрне армиягә куулары турында тоткыннар беләләр, шул хакта үзара көлеп сөйлиләр иде.* Г.Әпсәләмов. *Урамда чүпләнеп йөргән тавыкларга хәтле яныбызга килеп тыңлап тора башлады.* З.Мәхмүди

4) Баш килештәге исемнәр белән килеп, нәрсәнең дә булса күләмен, микъдарын башка бер нәрсә белән чагыштырып, тиңләштереп сөйләгәндә кулланыла; кадәр. *Кинәт агачлар арасыннан каршыбызга бозау хәтле овчарка килеп чыкты.* М.Хуҗин. *Кибән хәтле ирне култыклаган хатын әле сулга, әле уңга кыйшайды.* Н.Гыйматдинова

5) Вакыт һәм сан чиген билгеләү өчен кулланыла. *Туган-тумача дигәндә, гомеренең соңгы көненә хәтле җанын бирергә әзер булды.* А.Хәсәнов. *Ничек кенә булмасын, сәер тавыштан уянып китмәсә, ул әле таңга хәтле шундый татлы хыяллар дөньясында йөргән булыр иде.* А.Мансуров // Саннар һәм санны белдерә торган сүзләр белән килгәндә, нәрсәнең дә булса микъдар чиген күрсәтү өчен кулланыла. *Ташбакалар өч йөз елга хәтле яши, ди, имеш, әби менә шуны сынамакчы.* К.Кәримов. *«Сәгать сигезгә хәтле фәлсәфә түгәрәгендә булды» дигән язуны бирер әле, нигә бирмәсен...* М.Вәлиев

6) Иялек килешендәге алмашлыклар белән килеп, кемне яки нәрсәне дә булса сыйфат ягыннан чагыштыруны көчәйтү өчен кулланыла; кебек, төсле, шикелле. *Ә ул эшнең рәтен минем хәтле белүче юк!* З.Мифтахов. *Синең хәтле эшләгән кеше юк хәзерге көндә.* Г.Каюмов

7) Күрсәтү алмашлыклары белән килгәндә, сөйләмгә көчәйтү төсмере өсти: кадәр. *Шушы хәтле гадел кеше булсаң да булырсың икән!* З.Хәким. *И орышты, и орышты соң Юнысны: – Шунда хәтле кайтып, ачык ишектән керә алмагансың.* К.Кәримов // Нинди дә булса үзлек һәм үзенчәлекләрнең, сыйфатларның югары дәрәҗәгә җитүен

белдерү өчен кулланыла. *Бу хәтле тәмле ризыкларны Таһир кайчан күргән соң?* А.Хәсәнов. *Минем шушы яшемә җитеп моның хәтле шатланганым юк иде әле.* Н.Гыйматдинова

8) Кабатланган исемнәр арасында килеп, шул кешенең яки әйбернең бик мөһим булуына басым ясау өчен кулланыла. *Ат хәтле ат үлсә, ни көткәнен сабый акылы белән дә яхшы аңлый иде.* А.Әхмәтгалиева. *--- басуларның чүп үстереп зар елауларын, машина-тракторларның юк кына акчага сатылып, хәллерәк кешеләрнең йортларына күчеп утыруын, авыл хәтле авыл таралып бетеп барганын ни йөрәкләре белән тыныч кына күзәтеп, йомшак кәнәфиләрендә утырырлар иде икән?!* Г.Мирһади

9) *-ган* кушымчасын алган фигыль белән килеп, мөмкинлекнең чиген белдерү өчен кулланыла. *Үземнең унҗиде еллык гомеремдә соңгы биш айда уйлаган хәтле уйлаганым юк иде.* А.Гыйләҗев. *Котбетдин сөенә генә: – Сроксыз паспорт бирделәр – теләгән хәтле яшәргә була!* Ш.Галиев

**2.** *кис. функ.* Исемнәр белән килеп, мәгънәне көчәйтү өчен кулланыла. *Кайтам, кайтам туган якларыма – Талларыма хәтле сагынган.* С.Хәким

**ХӘТСЕЗ** *с.* **1.** Байтак, шактый, ярыйсы гына күләмдәге. *Авыр сал алай тиз генә туктыйсы итмәде, колгалар белән тыйсалар да, тагын хәтсез ара өстерәлеп барды.* А.Тимергалин. *Йоклый, имеш, берәү, өстәп-өстәп дару төймәләре йотты бит әле, беркатлы адәм, аларның тәэсире беткәнче бу егетне каравыллап утырырга туры килсә, хәтсез вакыт үтәргә тиеш.* К.Кара

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Бик күп, бик нык, шактый, бик каты. *Бу дөньяның көйсез көен көйләп Ялыктырган, хәтсез арылган.* Р.Вәлиев. *Кояш хәтсез кыздыра иде.* Х.Ибраһим

2) Бик озак, байтак, шактый вакыт, байтактан бирле. *Вертолёт, кояшлы киңлекләргә чикерткә күләгәсе ташлап, тирбәтә-тирбәтә, хәтсез очканнан соң, учак төтене күтәрелгән урман аланына төшеп утырды.* М.Галиев. *Перронда сез хәтсез юандыгыз – мин боларның бөтенесен күреп тордым.* Р.Юсупова

**ХӘТСЕЗДӘН** *рәв.* Күптәннән, әллә кайчаннан бирле, озак вакыт, байтактан; күптән. *Рәхимҗанның хәтсездән тавышы-тыны юк, әллә йоклаганмы?* А.Гыйләҗев. *Сәламәтлеге инде хәтсездән какшаган карт ана ишегалды тулы чәчәкләрен, бәлки, яшьли һәлак булган әнә шул туганы хөрмәтенә үстерәдер?* Т.Әйди

**ХӘ́ТТА** *кис. гар.* **1.** Үзе бәйләнгән сүз яки сүзтезмә алдыннан килеп, мәгънә төсмерен көчәйтү өчен кулланыла. *Хәтта минем синең белән сөйләшәсем килми.* М.Фәйзи. *Сөмсере коелган кызны хәтта юатырга тиеш тапты: – Берсе туктамаса, икенчесе туктар.* Ә.Баян

**2.** *терк. функ.* Эш-хәлнең яки нәрсәнең дә булса иң югары күрсәткеч билгесен белдергән җөмлә кисәкләрен яки җөмләләрне теркәү өчен кулланыла. *Ялның файдасы тиде: йөземә нур керде, хәтта чәчнең төсе үзгәрде.* З.Мәхмүди. *Мин, ачлыкта утырып, бөтен Казанга, Татарстанга, хәтта чит регионнарга да билгеле бер шәхескә әйләнгәнмен икән.* З.Зәйнуллин

**ХӘТТАТ** *и. гар.* Матур итеп, бизәкләп язу остасы; каллиграф. *Ул кульязмаларны махсус күчереп язучы осталар – хәттатлар барлыкка килгән.* Р.Миңнуллин

**ХӘТФӘ** *и. гар.* **1.** 1) Бәрхет. *Абыстай аңа зәңгәр хәтфәдән тегелгән күмеш каймалы камзул бүләк итте.* Г.Бәширов. *Аңа хәтфәдән махсус савыт эшләгәннәр, мәрмәр таш багана өстенә урнаштырганнар.* А.Гыйләҗев

2) *күч.* Бәрхет кебек йомшак, тигез үлән, чирәм. *Мин йөргән басулар хәзер яшел хәтфә белән капланды.* М.Мәһдиев. *Алар йөгереп үткән кырларда күкрәп игеннәр үсә, болыннар яшел хәтфәгә төренә.* Н.Гамбәр

**2.** *с. мәгъ.* 1) Шул материалдан тегелгән, ясалган. *Ничек моңарчы игътибар итмәгән ул моңа: Хәлимгә хәтфә кәләпүш шулкадәр килешә, исең китмәле!* Г.Бәширов. *Аяк йөзенә төшеп торган зәңгәр хәтфә халат кигән Сәхипгәрәйне шундук танып алды Мирсәет.* Р.Мөхәммәдиев

2) *күч.* Шундый тукыма кебек йомшак, тигез, нәфис. *Иртә әле, хәтфә үләннәр дә өлгермәгән чыгын коярга.* Р.Әхмәтҗанов. *«Юлың озак, олан, – диде ул, – әле син күп юлларның тузанын суларсың, хәтфә чирәмнәрнең йомшаклыгын арган аягың тоеп рәхәтләнер».* Р.Зәйдулла

**ХӘТФӘ́ГӨЛ** *и. бот.* Таҗгөлчәләр семьялыгыннан куе кызыл, сары яки әфлисун төсләрендә этәч кикригенә охшаган чәчәк ата, бакчаларда яисә бүлмә гөле буларак үстерелә торган үләнчел үсемлек; *русчасы:* **целозия гребенчатая**. *Менә аның үз кулы белән утыртылган бакча гөлләре: кашкарый, хәтфәгөл, алтын керфек.* Р.Төхфәтуллин. *Аның безгә халык телендә чыпчык тарысы, төлке койрыгы, әтәч кикриге, хәтфәгөл дип йөртелә торган, чүп үләне саналган кыргый сортлары гына билгеле.* Безнең гәҗит

**ХӘТФӘЛӘНҮ** *ф.* Хәтфә рәвешенә керү, хәтфә кебек булу; хәтфәгә охшый башлау. *Гаҗәеп төш күрдем: Ишегалдым Хәтфәләнеп бәпкә үләннән, Капкагача, рәт вә рәт үрелеп, Каз канаты белән түшәлгән!* А.Хәлим. *Җитмәсә, язның ташулары китеп, болыннарда бүз үлән хәтфәләнеп өлгерде.* Ф.Яхин

**Хәтфәләнә башлау** Хәтфәләнергә тотыну. *Болыннар хәтфәләнә башлады*

**Хәтфәләнеп килү** Акрынлап, азазлап хәтфәләнү. *Өйалды хәтфәләнеп килә икән инде, яланаяк йөрергә кирәк.* Мәйдан

**Хәтфәләнеп тору** Даими, әле, хәзерге вакыттта хәтфәләнү; хәтфәләнгән булу. *Хәтфәләнеп тора яшел үлән.* Ватаным Татарстан

**ХӘТФӘ́ҮЛӘН** *и. бот.* Таҗгөлчәләр семьялыгыннан куе кызыл вак чәчәкләре йомгакланып, чуксыман булып тупланган укмаш чәчәкле берьеллык үләнчел үсемлек; мәче койрыгы, песи койрыгы, песи талы, таҗгөл; *русчасы:* **амарант, ширица**

**ХӘЧТЕРҮШ** *с. фар. хурл.* **1.** 1) Шыксыз, ямьсез, кыяфәтсез, килбәтсез; уңай тәэсирләр уятмый торган; өтек, йолкыш. *Бу хәчтерүш бәндәне дә укытучылар тәрбияләгән бит.* Г.Әпсәләмов. *Шушы хәчтерүш кенә кызда күпме хәйлә, мәкер булыр дип кем уйлаган?* А.Гыйләҗев

2) Кечкенә, иске, сәләмә; кызыгырлык булмаган, башкалар белән чагыштырганда начаррак, кайтышрак тоелган. *Болак буендагы хәчтерүш кенә бер китапханәдә Анри Барбюсның Сталин турындагы китабын табып бирделәр.* Р.Юныс. *Ә инде хәчтерүш кенә бер «Москвич» та койрыгын күрсәткәч, түзмәдем: – Фиргатулла, «девятка»ны «Москвич» узарга тиеш түгелдер бит инде? – дип сорадым.* Т.Нәҗмиев

**2.** *и. мәгъ. хурл. кимс.* 1) Килбәтсез, шыксыз, өтек, йолкыш кеше, җан иясе. *Әйтәләр: «Безнең нәселдә Мондый бала тумас та... Бездә мондый хәчтерүшнең Булганы юк, булмас та!»* И.Юзеев. *Самат кияү бер хәчтерүш, энкеч булып чыкты.* Х.Ибраһим //

Тискәре сыйфатларга ия булган начар күңелле, яман, явыз кеше. *Кыланышы кырга сыймый хәчтерүшнең.* В.Имамов

2) Оешмаган, булдыксыз, уйланып бетмәгән эш-гамәлләр кылган кешедән көлеп әйтелә. *Роза аңа: «Их син, хәчтерүш, яратам дип алдашып йөргән булдың тагын!»* В.Нуруллин. *Шунда, ни гаҗәп, Тәскирә апалары ачуланмады, көлемсерәп кенә куйды: «Их сез, шушы яшькә җитеп, кем дәресеннән качарга ярый, кемнекеннән ярамый икәнен һаман аера белмисез икән әле, хәчтерүшләр!»* А.Гыймадиев

**ХӘШӘП** *и. гар. кимс.* Надан, ахмак. *Әй хәшәп, шуны оныткан!* А.Гыйләҗев. *Мәзин үзенең хатынына һәм башкаларга ахмак, хәшәп, надан, ябалак дип эндәшә.* Н.Фәттах

**ХӘШӘРӘТ** *и. гар.* **1.** 1) Һәртөрле җир-су хайваннары, сөйрәлүче хайваннар. *Аны чаян, каракорт ише берәр хәшәрәт чакмаган идеме?* Т.Әйди. *Тфү, хәшәрәт, бигрәк ямьсез инде шул бакалар, хе-хе-хе.* А.Гадел

2) Куркыныч җанвар; ямьсез, коточкыч җан иясе. *Житмәсә, төрле хәшәрәтләр – албастылар, шүрәлеләр, диюләр, ялмавызлар, убырлар да бар, имеш.* Г.Гыйльманов

3) Кешеләрне куркыта яисә аларга өстәмә мәшәкать, кыенлык тудыра, комачаулый торган хайван, кош-корт, бөҗәк һ.б.ш. *Кандала-мазар кебек хәшәрәтнең герман сугышыннан бирле күренгәне юк, диген.* А.Гыйләҗев. *Вадим, биегән шикелле, черки артыннан куа: «Барыбер тотам хәшәрәтне! Барыбер ботарлыйм, таптыйм...» – дип кычкырып ала.* Э.Яһудин

4) *сөйл.* Чит организм өстендә яки эчендә аның хисабына тереклек итүче җанвар (бет, борча һ.б.ш.). *Эчәк юлларына да төрле хәшәрәтләр ояларга гына тора бит.* А.Хәсәнов. *Шәмсенур апа балаларны бу хәшәрәтләрдән [бетләрдән] бик сакларга тырышты.* Т.Нурмөхәммәтов

5) *күч. сөйл.* Әшәке, үтә кабахәт, явыз кеше. *Эт кебек эштән арып кайтасың, ул хәшәрәт сине мыскыл итә.* К.Кара. *Мондый хәшәрәтләрне җирнең дә үз кочагына аласы килми.* А.Нәҗми

6) *күч.* Явыз дошман; һөҗүм итүче, начарлык кылучы кеше. *Бу хәшәрәтләр гаскәре көчле һәм бердәм.* А.Тимергалин. *Аның артыннан килгән хәшәрәтләр, паникага бирелеп, йөгерешеп китеп бардылар.* Р.Мөхәммәдиев

7) *күч. сөйл.* Кешеләргә бәхетсезлек, бәла-каза, начарлык китерә торган һәртөрле яман нәрсә. *Шушы хәшәрәт [алкоголь] нинди ир-егетләрне хур итеп ташламый.* А.Хәсәнов // Әшәке, пычрак, яман нәрсә. *Вагонның төрле урыннарына тотынганда, күпме хәшәрәт эләктерәбез.* Т.Нәҗмиев

**2.** *с. мәгъ.* Әшәке, явыз, кабахәт. *Бер хәшәрәт стукачның телен бераз тешләтеп алырга кирәк.* К.Булатова. *Ул, хәшәрәт җан, бер каныккач бетерә инде безне барыбер.* З.Зәйнуллин

**ХӘШӘРӘТЛЕК** *и.* Явызлык, янманлык, әшәкелек. *Ә хәзер, шайтаннан да яман кыланып, бер-берсен үтерү өчен әллә нинди хәшәрәтлекләр эшләп ташлыйлар.* С.Поварисов. *Хәтмулладан туган баланың менә шундый хәшәрәтлеккә төшүе икеләтә аяныч иде.* М.Кәбиров

**ХӘШИШ** *и. гар. к.* **гашиш**. *Юридик әдәбият сәхифәләреннән күренгәнчә, ислам дөньясында хәшиш IV–IX гасырларда гына кулланылышка кергән булырга тиеш.* А.Тимергалин

**ХӘЯ** *и. гар. иск.* Оят; намус. *Хәя бетте, хәя беткәч, иман бетте.* Г.Исхакый. *«Бөтен дөньясы буталды, намус-хәя калмады», – дип, үзеңнең дә зарланырга хакың калмый ич!..* Б.Рәхимова

**ХӘЯСЫЗ** *с. гар.* Оятсыз; намуссыз. *Хәясыз бәндәдерсең, оят белсәң, күрексез кыяфәттә урамга чыкмас идең.* М.Хуҗин. *Көпә-көндез, хуҗалары күз алдында йорт басарга, түбә калайларын куптарып, металлоломга тапшырырга ният итеп килгән хәясыз угрылар хакында монда гадәти нәрсә турында сөйләгән кебек бәян итәләр.* Татарстан яшьләре

**ХӘЯТ** *и. гар.* Тормыш, яшәеш, тереклек. *Юкка гына, хәят көчлеләр кулында, мәхәббәттә куәтлеләр өстен чыга, дип әйтмиләр икән.* Т.Галиуллин. *Кешенең хәяты шундый: яки ул якты йолдыздай балкып үтә, яки адашкан җансыз ялгыз очкындай юкка чыга.* А.Нәҗми

**ХЕ́ДЕР** *и. ингл. а.х.* Комбайнның иген сабакларын кисә торган ургычы. *Тизлекне тоташтырып педальгә басуга, аякларны чымырдатып, тәненә бер төрле рәхәтлек йөгерде – комбайн, чайкала-чайкала, әкрен генә урыныннан кузгалды, хедер канатларын җилпеп, алдына арышларны баш идерә башлады.* Ш.Бикчурин. *Сул якта, шаулап, калай торба стеналары буенча шуышып, бункерга коры, авыр арыш коелды, һәм хедер артыннан чип-чиста булып кыркылган тигез камыл тырпаеп калды.* Н.Фәттах

**ХЕЗМӘТ** *и. гар.* 1) Кешедән акыл яки физик көч таләп итә торган максатлы эшчәнлек, эш. *Колхоз рәтсез булганга, хезмәт көненә аз тия.* Х.Туфан. *Гомернең ил өчен, хезмәт өчен, рәхәт өчен дигән өлешләре бар.* А.Гыйләҗев

2) Көч, энергия, тырышлык. *Рус тел коллективының хәзерге көчле әдәби теле мәйданга килүе өчен Карамзин, Жуковский, Грибоедов, Пушкин, Гоголь, Тургенев, Толстой һәм Достоевский... кебек рус әдәбият даһилары азмы көч һәм хезмәт салганнардыр.* Х.Бәдигый. *Бушка түгел, шушы җиргә кергән хезмәтең өчен.* Г.Сабитов

3) *сөйл.* Вазифа, эш (урыны). *Урман каравылчысы булу – бик начар хезмәт ул.* Т.Гыйззәт. *Студентларга булачак хезмәт урынын сайлау хокукы бирелә, Атилла Дагстан якларына китеп бара.* Р.Зарипова

4) Роль, функция (нәрсә урынына булса да кулланылу, файда китерү тур.). *Казан «барабыз»лары – шәһәрдә автобус хезмәтен үти торган җигүле атлар.* Һ.Такташ. *Менә шундый тамгалы ташлар борынгы заман кешесенә хәзерге паспорт хезмәтен үтәгән.* Н.Фәттах

5) Гражданнарның кораллы көчләр сафында закон белән билгеләнгән бурычын үтәве һәм илне саклау белән бәйле башка эшләр башкаруы. *Хезмәттән кайтып, атна-ун көн вакыт үттеме-юкмы, эшкә чыгарга теләде.* Ж.Дәрзаман. *Хезмәткә баручылар бер Өметбай гына түгел бит.* Д.Бүләков

6) Эшчәнлекнең, эшнең нәтиҗәсе; фәнни, әдәби яки берәр төрле сәнгать әсәре. *Фазылҗанның бу хезмәте бигүк җитди фәнни хезмәт түгел, минемчә.* Г.Әпсәләмов. *Чарасызлыкны, Вакыт кодрәтенә беркемнең, бернәрсәнең дә каршы торалмаганын белсә дә, Иҗатчы, Вакытның «ялына ябышып булса да», хезмәтләре белән, Аңа үз исеме белән мөһер суга.* Р.Фәйзуллин

7) Мактаулы исемнәр составында кулланылып, хезмәтендә зур уңышка ирешкән, дигәнне аңлата. *Түшенә Хезмәт Кызыл Байрагы ордены тагып йөрү турында хыяллана икән ул.* М.Маликова. *Ул 3 нче дәрәҗә Хезмәт Даны ордены белән бүләкләнде.* Т.Нәҗмиев

◊ **Хезмәт җимеше** Нинди дә булса эшнең нәтиҗәсе. *Дәүләт байлыгы – ул сезнең кебек, минә минем кебек*

*миллионнарча эшче халыкның хезмәт җимеше*. М.Хәсәнов. *Шәһәрдә уңайлы фатиры бар, анысы да – хәләл хезмәт җимеше.* Т.Әйди. **Хезмәт кенәгәсе** Хезмәткәрнең эш стажы, вазифасы, эшләү дәверендә штатка бәйле үзгәрешләр, исем бирелү, бүләкләнү һ.б. язып барыла торган документ. *Кадрлар бүлегендә Җәмилнең анкетасын, хезмәт кенәгәсе һәм башка кәгазьләрен ул инде күңелсез, әмма котылгысыз бер бурычын үтәгән кебек кенә күздән кичерде.* Т.Әйди. *Шул көннән үк миңа хезмәт кенәгәсе ачып, «Хезмәтен бик белеп һәм тырышып башкарган өчен, гади ат караучыдан хуҗалык мөдире итеп күтәрергә» дигән приказ яздылар.* А.Хәсәнов. **Хезмәт кую** Эш башкару, тырышлык кую. *Минем бүгенге уңышларымның шушы кайгыборчуларны җиңеп, зур тырышлык, шактый хезмәт куеп ирешелгәне дә аларга мәгълүм.* А.Нургалиева. *Без – имам, мөфти, казыйлар – Русия, Татарстан өчен зур хезмәт куябыз.* Г.Газиз. **Хезмәт күрсәтү** Кем өчен дә булса билгеле бер эш башкару; ярдәм итү. *Янгыннан зыян күргәннәргә хезмәт күрсәтә*. Ш.Маннапов. *Аллага шөкер, хөкүмәтебез халыкка мәдәни хезмәт күрсәтү бүгенге көндә бары тик дәүләт тарафыннан финансланырга тиешлеген дөрес аңлап эш итә.* Ю.Сафиуллин

**ХЕЗМӘ́Т ИТҮ** *ф.* 1) Эшләү. *Аларның әле шактый еллар хезмәт итәсе, тормышларын корасы, алга таба юл сабасы бар.* З.Зәйнуллин. *Үзем бу журналда җәмгысы 25 еллап хезмәт итәм.* Л.Әбүдәрова

2) Хәрби хезмәттә булу. *Флотта хезмәт итү – дөньядагы барлык башка төр эшләргә караганда иң абруйлы, иң дәрәҗәле эш икән.* М.Мәһдиев. *Әфганда бергә хезмәт иткән идек.* Р.Габделхакова

3) Кем өчендер эшләү, башкалар кушкан эшне, йомышны башкару. *Исламия ханым олы гаиләгә хезмәт итеп (кайната, кайнана һәм һәркайсы үз холыклы алты каенсеңел), буйсынып яшәсә дә, эчке бәйсезлеген югалтмый.* Т.Галиуллин. *Дөрес, ире Бәкер ага аны алай озак каенанага хезмәт иттермәде, ике-өч көн дигәндә башка алып та чыкты*. Ф.Яхин

4) Хезмәтче, ялчы булу, ялланып эшләү, ялчылык итү. *Патруль булып Герман сугышыннан кайткан, утнысуны кичкән татар солдатлары, бистәдә яшәүче татарлар, шәкертләр, байларда хезмәт иткән сатучы-приказчиклар, хәтта авылдан «үзебезнең татар хакимиятенә ярдәмгә килгән» авыл кешеләре дә хезмәт итә.* З.Зәйнуллин

5) Кем яки нәрсә өчен файдалы, кирәкле булу, көч кую, тырышу; кешеләрнең күңелен, рухын күтәрү, аларга рухи азык бирү һ.б. өчен иҗат итү, халыкка файдалы гамәлләр башкару. *Талант халыкка хезмәт итәргә тиеш.* С.Хәким. *Халыкка хезмәт итү ул – Мәңгелеккә омтылу дигән сүз дә.* Р.Фәйзуллин

6) Өлеш кертү, ярдәм итү, файдалы булу. *Әлеге журнал шул максатка хезмәт итәр иде ләбаса!* Ш.Галиев // Ярдәм итү, файда китерү (йорт хайваннары һ.б. тур.). *Ул бала чагыннан ук шул чылбырда йорт каравыллап, Хуҗасына бик күп хезмәт иткәнгә, Хуҗа да бу Этне бик сөя иде.* Г.Тукай

7) *күч.* Нинди дә булса башка максатларда файдаланылу; билгеле функция үтәү, берәр роль, вазифа үтәү. *Шешәнең авызыннан чыгып торган күмерле тасмага карап, Гөлсем апа аның лампа урынына хезмәт иткәнен белде һәм шырпы сыза башлады.* Г.Гобәй. *Ау, сунар кораллары булып, таяк – тәпәч, тимер башлы сөңге яисә озын пычак хезмәт итә.* Г.Гыйльманов

8) *күч.* Файдалы булу, нәрсә белән дә булса тәэмин итү, ярдәм итү. *Уралтауның кырык сырты кырык гасыр буе татарларга хезмәт иткән.* Ф.Бәйрәмова. *Табигать гомер-гомергә кешегә хезмәт итеп килгән, хәзер дә хезмәт итәргә тиеш.* Р.Вәлиев

9) *күч.* Булу, тору, кулланылу. *Андагы факт-мәгълүматлар, фикеркүзәтүләр әле озак еллар буе галимнәр, мөгаллимнәр, укучылар өчен төп таяныч, ышанычлы чыганак булып хезмәт итәчәк.* Х.Миңнегулов // Үз эшен башкару. *Кабатлап булса да башта шуны әйтим: иң мөһиме, закон тиешенчә хезмәт итәргә тиеш*. Р.Миңнуллин

10) *күч.* Файдалануда булу, кулланылу; файдалы булу, файда күрсәтү, үз функциясен үтәү, кешеләр һ.б. өчен кирәк булу. *Гомер буе хуҗасына хезмәт итеп, хәзер карачкы башына элеп куелган эшләпәнең язмышыннан көлергә ярыймы?* Т.Миңнуллин. *Шәүкәт абый миңа чәй ясап биргәч, әллә кайдан гына – өстәлнең билгеле бер почмагыннан – рәсемнәре юылып, ашалып беткән, озак хезмәт итүдән инде кечерәеп тә калгандай чынаяк тәлинкәсе алды.* З.Гыйльметдинова

11) *күч.* Йогынты ясау, этәргеч булу, нәрсәгәдер ярдәмче булып тору, булышу. *Кайбер очракларда ул әсәрне чынбарлык чикләреннән алып чыгып китә, яшәеш һәм теге дөнья хакында уйлануларга этәрә, нindидер фәлсәфи фикер уятуга хезмәт итә.* Д.Заһидуллина. *Галимнәр карашынча, югарыдагы төп поэтик алым хисләрнең масштабын арттыруга, аларны киеренкеләндерүгә хезмәт итә.* Р.Харрасова

**ХЕЗМӘ́Т ИЯСЕ** *и.* Хезмәт итүче, эшче кеше, хезмәтчән. *Иң элек тегермәннәр үз тирәсенә күп кешеләрне эшкә тарта, ягъни монда яңа хезмәт иясе – эшчеләр катлавы барлыкка килә.* Ә.Еники. *Хезмәт иясе һәм милләтләр турында кайгырту – сүздә генә...* Р.Мөхәммәдиев

**ХЕЗМӘТКӘР** *и.* 1) Җитештерү өлкәсенә карамаган төрле оешмаларда эшләүче кеше. *– Ханзафаров Мөстәкыйм Максутович, илле биш яшь, хезмәткәр, – дип таныштыра башлады Маһирә ханым.* Г.Әпсәләмов. *Вак-төяк хезмәткәр генә түгел, түрә булып йөри.* Х.Ибраһим

2) *иск. к.* **хезмәтче** (*1 мәгъ.*). *Шулай булгач, сине байлык эчендә, каршыңда хезмәткәрләр, асраулар торган хәлдә күрүдән ни өчен шат булмыйм?* Г.Камал

**ХЕЗМӘТТӘШ** *и.* Кем белән дә булса бергә эшләүче, бер урында хезмәт итүче кеше. *Синең хезмәттәш дусларың мине төрлечә юатырга тырышты, әмма кемнең ни әйткәнен, нинди киңәш биргәнен аңламадым*. Ф.Яруллин. *Ул һәрвакыт үзенә һәм хезмәттәшләренә таләпчән булды.* Г.Мөхәммәтшин

**ХЕЗМӘТТӘШЛЕК** *и.* 1) Нинди дә булса эштә катнашлык, ярдәм. *Нәкыйга аклар армиясенә хезмәттәшлек күрсәтүдә гаеп тагыла.* З.Сөнгатуллина

2) Берәр өлкәдә бергәләп, киңәшләшеп алып барыла торган эш-хәрәкәт, эшчәнлек. *Шик тә юк ки, алар арасында тату хезмәттәшлек, сәүдә бәйләнешләре да тамыр җәйгән, әмма тарих хәрби бәрелеш, сугышларны гына теркәп калдырган.* Т.Әйди. *Гомумән, чын дуслык, хезмәттәшлек тигезләр арасында гына була ала.* Р.Фәйзуллин

**ХЕЗМӘТТӘШЛЕ́К ИТҮ** *ф.* 1) Кем белән дә булса бер төрле эшчәнлек алып бару; бергә эшләү, киңәшеп, ярдәмләшеп эшләү. *Һәм безнең белән, шулай ук хокук саклау органнары белән дә хезмәттәшлек итсәгез, бик рәхмәт-*

*ле булыр идек.* З.Хәким. *Шуңа күрә дә аның белән хезмәттәшлек итәргә икеләнеп тормыйча ризалык бирә.* К.Җәмит

2) Нинди дә булса оешманың хезмәткәре булу. *Кырымда «Тәрҗеман» гәҗитендә дә хезмәттәшлек итүе мәгълүм.* Х.Миңнегулов

**ХЕЗМӘ́Т ХАКЫ** *и.* Хезмәткәрнең квалификациясенә һәм эшләгән эшенең күләменә, сыйфатына карап, күрсәтелгән хезмәт өчен түләнә торган акча; эшләгән эше өчен хезмәткәр ала торган акчалата компенсация, эш хакы. *Кичә генә алар беренче хезмәт хакын алдылар.* А.Алиш. – *Күп тавышлансагыз, минем хезмәт хакын кисеп куярлар, шул булыр, – дип кисәтү ясагандай итте дә өстәл тутырып яткан кәгазьләренә иелде.* А.Әхмәтгалиева

**ХЕЗМӘТЧӘН** *и.* **1.** 1) Эшләүче кеше; хезмәт итүче кеше; хезмәт иясе. *Төзелешләр мәйданын хәтерләткән республика тормышында майлы киемле хезмәтчәннәрдән тыш идарәчеләр, югарыдан куелган стратегик максатны тормышка ашыручылар катламы – Табиевлар, Шмарёвлар, Васильевлар, Шашиннар, Мингәрәевләр, Лемаевлар, Бехлар һәм тагын күпләр бар иде.* Р.Фәйзуллин. *Язучының хикәя геройлары – ихлас күңелдән яратып сурәтләнгән олылар, гомерләрендә күпне күргән хезмәтчәннәр, тормышны сөеп яшәүче милләттәшләребез.* Ә.Хәсәнов

2) Билгеле бер өлкәдә, тармакта эшләүче, хезмәт куючы кеше; эшче, хезмәткәр. *Кала хезмәтчәннәре белән искиткеч җылы очрашудан соң, безне Җаек (Урал) елгасы буйлап күңелле сәяхәткә алып чыктылар, хөрмәтләп кунак иттеләр.* И.Юзеев. *Әйе, ул – авыл хезмәтчәннәренең иң олы бәйрәме!* Р.Рахман // Оешма, предприятие хезмәткәре. *Мәдәният сарае Оргсинтез хезмәтчәннәре өчен әле быел гына корылды.* Р.Кәрами. *«Татспиртпром» хезмәтчәннәре данлы «Казан утлары»н 75 еллык бәйрәме белән чын күңелдән тәбрик итә.* Казан утлары

3) Бик тырышып һәм бик күп эшли торган кеше. *Дистәләгән еллар буена чын хезмәтчәннәр яшәгән, хайваннарны, кош-кортларны чын күңелдән сөйгән йорт өчен бу коточкыч көннәр иде.* Я.Шәфыйков. *Флёра Садриевна Сафиуллина бөтен гомерен, кайвакыт тәттә тәүлекләрнең һәр сәгатен-минутын фәнни эшкә сарыфлаган фидакарь хезмәтчәннәрнең берсе иде.* Р.Рахман

4) Бөек Ватан сугышы елларында тылда хезмәт куючы; тылчы. *Хәзер тыл хезмәтчәннәренә «Бөек Ватан сугышы ветераны» дигән танылыклык бирелә башлады.* З.Мәхмүди. *Казандагы Ирек мәйданына җыелган сугыш һәм тыл хезмәтчәннәрен Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов котлады.* Казан утлары

**2.** *с. мәгъ.* Эшчән, эшне ярата торган, булдыклы, тырыш, уңган. *Ә халык авыз иҗатында барлык мөселман халыкларында хатын-кызлар ана булулары, якты акыллы, сәләтле, хезмәтчән булулары өчен зур ихтирам белән телгә алына.* Л.Шәйдуллина. *Әсәрдә утызынчы еллардагы ерткычлыклар, кырыгынчы-илленче-алтмышынчы еллардагы башсызлыклар һәм шул җирлектә кемнәрнеңдер хирыска бирелеп түбәнгә тәгәрәве, ә кемнәрнеңдер, намусын сатмыйча, кешелекле һәм хезмәтчән булып калулары сурәтләнә.* И.Сабиров

**ХЕЗМӘТЧЕ** *и.* 1) Хуҗаның йомышларын үтәүче кеше, байларда төрле хуҗалык эшләрен башкаручы; ялчы, хадим. *Безнең әти дә, мин дә аңарда хезмәтче булып тордык.* А.Алиш. *Хәл кереп, өй тирәсендә йөри башлаган Гөлнәзирә һаман ачылып китеп сөйләшми, буйсынучан хезмәтче кебек, Газинур нәрсә кушса, шуны эшләп тик йөри.* Г.Гыйльманов

2) *к.* **хезмәткәр** (*1 мәгъ.*). *Китапханәдә яшь хезмәтче Лилия туташ Алимханова белән таныштым, ул биредә җәйге каникулларда эшли икән.* М.Миначев. *Син – хезмәтче, алар – түрә, Син эшлисең, алар булә.* Ф.Дәүләтбаев

3) *күч.* Кемнең дә булса мәнфәгатьләрен үтәүче, кайгыртучы, яклаучы; кем яки нәрсә өчен тырышучы, аның уңышлары өчен хезмәт итүче; хадим. *Гыйлаҗетдин хәзрәт бер авылның имамы, халык хезмәтчесе була.* Г.Исхакый. *Якын арада гына «халык хезмәтчесе» затлы йорттан, шәһәр уртасыннан фатир алган булып чыга.* Т.Галиуллин

**ХЕЗМӘТЧЕЛ** *с.* 1) Үз хезмәте белән көн күрә торган, хезмәт белән яши торган. *Бу көрәш бөтен хезмәтчел кешелек интереслары өчен алып барыла, һәм куркаклар, түбән җанлы кешеләр генә ул көрәштән качарга мөмкиннәр.* М.Мәһдиев. *Беренче империалистик сугыштан тәмам йончыган һәм туйган барлык милләт хезмәтчел халкы февраль буржуаз революциясеннән көткәнен ала алмый ---.* Н.Таҗдарова

2) Эш сөючән, тырыш. *Без бетәрбез, без сүнәрбез, ә синең даһиең дөнья күгендә һаман балкыр, шундый-шундый бер халык булганлыгын, кайчандыр шундый бер хезмәтчел, шундый бер шагыйрь җанлы тырыш халык яшәгәнлеген исбат итеп һаман ялтырар, һаман балкып торыр!* Г.Бәширов. *Хәзер алар Иделне яр читеннән беренче мәртәбә күргән кешедәй хәйран калучы кыюсыз яшүсмерләр түгел, ә эштә чыныккан, Иделгә ихлас күңелдән гашыйк, хезмәтчел елгачы буларак үсеп киләләр.* С.Сабиров

**ХЕЗМӘТЧЕЛЕК** *и.* Хезмәтче (*1 мәгъ.*) булу. *Хәдичә бер байга хезмәтчелеккә ялланды.* С.Поварисов. *Казан арты крестьяннары, нигездә, ике якка миграция кичерәләр: беренчесе – Казан шәһәренә – ялчылыкка, хезмәтчелеккә.* М.Мәһдиев

**ХЕЗМӘТЧЕЛЛЕК** *и.* Хезмәтчел булу, тырышлык, эш сөючәнлек. *Үз буыны язучылары арасында ул, ихтимал, акрынлык белән, мәшәкатьле, күпкырлы эшчәнлеге, гадәттән тыш хезмәтчеллеге белән абруйга ирешкән азлардан берседер.* Н.Фәттах

**ХЕ́ЙТЕР** *и. ингл.* Кемгә яки нәрсәгә дә булса каршы булып, яратмыйча, күралмыйча, шуны кимсетергә, мыскыл итәргә тырышучы кеше (башлыча Интернет челтәре аша). *Интернет челтәрендә мондый хейтерларга (мыскыллаган кешеләрне шулай дип атыйлар) ничек каршы торулары, агрессиягә җавап кайтармаулары турында күбрәк сөйләсәләр, яшүсмерләр үзләре үк проблемаларының хәл итеп булырлык икәнлеге турында беләчәк.* Сабантуй

**ХЕ́ЙТЕРЛЫК** *и.* Хейтер гамәлләре; хейтерлар шөгыле. *Без аның хейтерлыгы турында белми идек*

**ХЕ́ЙТЕРЧЫ** *и. ялг. к.* **хейтер**

**ХЕ́ЙТЕРЧЫЛЫК** *и. ялг. к.* **хейтерлык**. *Интернетта хейтерчылык очраклары арткан икән, мондый көрәнеш җәмгыятьтә күбәйгән дигән сүз.* Ватаным Татарстан

**ХЕК** *и. ингл. зоол.* Тәрәччәләр семьялыгыннан диңгездә яши торган промысел балыгы. *Шуңа бераз кәефсезләнә, мыгырдана Гасыйм абзаң, ләкин башка җиргә кереп тормый, чөнки «Татар ашлары»ннан башка җирдә аңа ярарлык ризыгы юк та диярлек (хек белән дуңгызны, гафу итсеннәр, аның нәфесе кабул итми)...* Ә.Еники. *Балыкка килгәндә, мәктәпләрдә хәзер минтайдан*

*тыш, горбуша, хек, тәрәч балыклары булачак.* Мәйдан

**ХЕ́-ХЕ** *иярт.* Әкрен генә тавыш белән астыртын көлүне белдерә. – *Хе-хе, – дип көлемсерәде гарәп сатучысы, биленә таянып.* Н.Фәттах. *Нәрсә хәзер, Рәшидәнең күңеле бай, акчасы гына юк дип, акча җыеп бирикме, хе-хе-хе*! Г.Каюмов

**ХЕШТЕ́Г** *и. ингл.* Микроблогларда һәм социаль челтәрләрдә билгеле бер темадагы, эчтәлектәге хәбәрләрне эзләп табуны җиңеләйтә торган рәшәткә билгесе (#) белән башланып киткән ачкыч сүз яки сүзләр. *Фейсбукта хештеглар бик яхшы эшләми, шуңа күрә, бу фикерләр, терминнарның тәрҗемә вариантлары югалмасын дип, «Татарча ничек?» дигән төркем булдырдым.* А.Мөхәммәтҗанов. *Студентлар, актив яшьләр үз битләрендә фотоларны шушы хештег белән урнаштырачак.* Шәһри Казан

**ХИАЗМ** *и. гр. лингв.* Мәгънәне көчәйтеп бирү өчен, фразаның бер үк сүзләрен урыннарын алмаштырып кабатлаудан гыйбарәт стилистик фигура (мәсәлән, *елый да көлә, көлә дә елый*). *Хиазм урнашканда, җөмләнең ике өлеше дә эчтәлек, структурасы һәм интонациясе буенча капма-каршы була: Якты барга беленә караңгылык.* Татар лексикологиясе. *Кире кабатлауларның бары тик беренчесе генә хиазм күренеше итеп карала ала.* Фәнни Татарстан

**ХИА́ЗМА** *и. гр. анат.* Мидә күрү нервларының бер-берсе белән кисешкән урыны. *Хиазма зарарлану*

**ХИҖАБ** *и. гар.* 1) *иск.* Пәрдә, чаршау; каплау

2) Ислам динен тотучы хатын-кызларга фарыз булган, баштанаяк гәүдәне каплый торган теләсә нинди кием. *Дүрт ай дигәндә, кыз, ислам динен кабул кылып, Зоядан Зәйтүнәгә әйләнә, өстенә хиҗаб киеп, намазлыкка баса.* Г.Гомәр. *Хиҗабның зур җаваплылык икәнен онытырга ярамый, чөнки җәмгыять яулыклы мөслимәгә шәхес буларак кына түгел, ә бөтен мөселман өммәтенең бер вәкиле итеп карый.* Безнең гәҗит

**ХИҖАБСЫЗ** *с.* **1.** 1) Ислам кануннарына туры килерлек итеп киенмәгән, хиҗаб кимәгән. *Ул авылларда хиҗабсыз хатын-кызны бик сирәк очратырсың.* Мәдәни җомга

2) *күч. иск.* Оятсыз, битсез. *[Шәйхезаман:] Тукта, дим, хиҗабсыз! Сугып үтермәс борын күз алдымнан алыгыз!* Т.Гыйззәт

**2.** *рәв. мәгъ.* Хиҗаб кимичә

**ХИҖАМӘ** *и. гар.* Мөселманнарда тәннең йомшак тукымаларына үткен корал белән вак-вак ярыклар ясап вакуум белән кан алдыру ысулы. *«Бернинди дә зарар юк, матурым, мин болай да хиҗамә ясамакчы идем (шәригатьчә кан алдырмакчы идем), син минем акчаны да, вакытны да сакларга сәбәп кенә булдың», – дип, тагын хатынын юата.* Сөембикә. *Кан алдыруны икенче төрле хиҗамә дип тә йөртәләр, чөнки Мөхәммәд галәйһиссәлам аны нәкъ менә шулай атый.* Безнең мирас

**ХИКӘЯ** *и. гар.* **1.** 1) *әд.* Чәчмә белән язылган кечкенә күләмле әдәби әсәр; шундый әсәрләр жанры. *Әмма хикәя язу ул әле үзеңне хикәя остасы дип таныту дигән сүз түгел.* А.Хәлим. *Моны да кызык хикәя итеп язарсың әле, сиңа ышансаң.* Ф.Баттал

2) Телдән сөйләнгән нинди дә булса вакыйга, булган хәл. *Мин сезгә моннан күп-күп еллар элек, Әби патша заманында ук булып узган хәлләрдән бер чын хикәя сөйләмәкче булам.* Г.Рәхим. *Заманында Көрнәледә укыткан теге Гөлүсә белән тагын бер мәртәбә очрашуымны әйтми калдырсам, хикәям тулы булмас төсле.* В.Нуруллин

**2.** *с. мәгъ. лингв.* 1) Эчтәлеге нәрсәне дә булса раслаудан яки инкяр итүдән гыйбарәт булган (җөмлә). *Синтаксик чара – сөйләүченең мөнәсәбәте әйтелү максаты буенча җөмлә төрләре аша белдерелә: хикәя җөмлә, сорау җөмлә, тойгылы яки өндәү җөмлә һ.б.* Ф.Хисамова. *Мәсәлән, гадәти сүз тәртибе белән төзелгән җыйнак хикәя җөмлә тыныч тон белән әйтелгәндә синтагмаларга бүленми.* Ш.Асылгәрәев

2) Эш яки хәлнең булу-булмавын хикәяләү, хәбәр итү рәвешендә белдерә торган (фигыль формасы). *Боерык фигыль, теләк фигыль формалары – чын күңелдән гафу үтенгәндә, ә хәзерге һәм киләчәк заман хикәя фигыль формалары әдәп өчен генә, формаль гафу үтенүдә файдаланыла.* Р.Абдуллина. *Хәбәре үткән заман хикәя фигыль белән белдерелгән җөмләләрнең янәшә күп килүе теләсә кайсы текстны ямьсез итә.* Р.Рахман

**ХИКӘЯ́ ИТҮ** *ф.* Сөйләү, тасвирлау, хикәяләү. *Аның кулында атаклы галим академик Павлов тормышын хикәя иткән китап иде.* Г.Кутуй. *Сәгатьләр буена кызыма үзенең әсәрләрен укыган, тормыш хәлләрен хикәя иткән, башыннан кичкән вакыйгалар хакында сөйләгән.* С.Ибраһимова

**ХИКӘЯЛӘ́Ү** *ф.* 1) Нинди дә булса хәл, вакыйга турында җентекләп сөйләү, бәян итү; тасвирлау. *Рәшит Нәҗметдинов, шахмат партиясен анализлаганда, дәрәҗәсен белеп, кайбер урында тәфсилләп, кайчак кырт борылышлар ясап, әмма аңлаешлы итеп, оста хикәяли иде.* М.Хуҗин. *Мин, Әхәт абзыйның берәр мөһим вакыйганы хикәяләү алдыннан, шулай озак итеп, авылның тоткан урыны, башыннан үткәннәре турында тәмләп сөйләргә яратуын күптән белгәнлектән, сабырсызлык күрсәтүдән тыелдым.* И.Диндаров

2) Эзлекле рәвештә вакыйгаларны сурәтләп язу. *Элегрәк иҗат ителгән байтак хикәяләрендәге кебек, монда да әдип рухи-интеллектуаль яссылыкта хикәяли.* М.Хуҗин. *Мәсәлән, «Безнең өй өянкеләр астында иде...» әсәрендә язучы үзе күргән-катнашкан вакыйганы хикәяли.* Фәнни Татарстан

**Хикәяләп алу** Тиз генә хикәяләү; тиз арада хикәяләү. *Бу сорауга җавап бирү өчен, Вәлиулла иң элек үзенең кем булуын, кайда туып үскәнлеген, сугыш михнәтләре кичәргә туры килгәнлеген кыскача хикәяләп алды.* Р.Низамиев

**Хикәяләп бирү** Башка берәү өчен хикәяләү. *Инде, ниһаять, сөйләп кенә түгел, хикәяләп бирергә дә тулы хокукым бар диеп беләм.* Р.Мөхәммәдиев. *Дөрес, башта ул көтмәгәндә-чакырмаганда килеп кергән кешегә шикләнебрәк карады, ләкин сөйләшә торгач ачылып китте һәм белгәнен хикәяләп бирде.* З.Мурсиев

**Хикәяләп узу** *к.* **хикәяләп үтү**. *Журнал вариантында әдип вакыйгаларның иң ахырына килеп төшә дә аңа хәтле булган хәлләрне Хәлимнең искә төшерүе рәвешендә генә хикәяләп уза иде.* Ф.Хатыйпов

**Хикәяләп үтү** Сүз яки эш уңаеннан хикәяләү. *Хәзер ашыкмыйча гына, иплән-җайлап кына шул хакта хикәяләп үтим әле, яме, мөхтәрәм укучым!* Т.Нәҗмиев

**Хикәяли башлау** Хикәяләргә тотыну. *Бүрәнә өстенә утыра, башта агач аягына кага-кага төрепкәсен чистарта, яңа тәмәке тутырып, паровоз кебек төтен чыгара да әкрен генә хикәяли башлый ---.* И.Кашфразыев. *Соңга таба «мин» исеменнән язылган әсәрләрдә теге яки бу иҗтимагый катлам вәкиле хикәяли башлый, һәм, шуларга бәйле рәвештә, хикәяләү бертөслелектән, күпсүзлелектән котыла.* Ф.Сафиуллина

**ХИКӘЯТ** *и. гар. сөйл. к.* **хикәя** (*2 мәгъ.*). *– Һәм алар бик-бик бәхетле, тигез гомер итәләр, – дип, хикәятне үзенчә дәвам итте Сәрия.* А.Тимергалин. *Шул вакыт ишектә Мәхмүтнең баягы маҗаралы хикәятен тыңлаучыларның берсе – Кыш бабайга охшаган карт күренде.* А.Вергазов

**ХИКӘЯЧЕ** *и.* 1) Хикәяләр язучы. *Хәсән Сарьян тиз арада – өч-биш ел эчендә – оста хикәяче булып танылды.* М.Шабаев. *Әдәбиятта мин агачтан эшләнгән барлык әйберләр яңадан яфрак яран дөнья тудыруны ниятем иттем, диган Баш хикәяче.* М.Хуҗин

2) Матур итеп сөйләүче, оста итеп сөйли белүче; сөйләүче. *– Ничек егылмаган?.. – дип авызымны гына ачкан идем, хикәяче: – Тукта, сабыр ит, бу гынамы әле?.. – диде.* Х.Миңнегулов. *Хикәяче, тавышына мөмкин чаклы ваемсызлык, битарафлык төсмере бирергә тырышып, өстәп куйды: – Чынында, ышану-ышанмау Сезнең ихтыярда.* Т.Галиуллин

**ХИКМӘТ** *и. гар.* **1.** 1) *әд.* Гыйбрәтле вакыйганы тасвирлаган кыска гына кызыклы хикәя, мәзәк. *Татар поэзиясендә Мәүлә Колый «Хикмәтләр»е дә, Габделҗаббар Кандалый сатирасы да, Акмулла һәм Дәрдемәнд лирикасы да, Сәгыйть Рәмиев романтизмы да һәм Фәнияр белмәгән тагын дөнья кадәр шагыйрьләр бар икән.* Ф.Яруллин. *Алар, тормыш тәҗрибәләренә һәм күзәтүләренә таянып, кыска-кыска хикмәтләр әйтеп калдырганнар.* А.Тимергалин

2) Сәер хәл; гаҗәпләнерлек нәрсә; искиткеч, аптырарлык хәл; кызыклы хәл, вакыйга. *Ул үсмерләрнең, берберсенә ирек бирмичә, йотлыга-йотлыга, Болак буендагы хикмәтне сөйләгәннәрен дәшми генә тыңлап торды.* Д.Гыйсметдин. *Һәркем үзенең кылган «батырлыгы», күргән хикмәтләре турында шул дәрәҗәдә рухланып сөйли ки, хәтта үзләре дә үз ялганнарына ышана төсле тоела.* Л.Надыршина

3) Сер, эчке мәгънә; нечкәлек. *Галим, тормышның барлык хикмәтләрен белгән, һичнәрсәгә исе китмәгән карт бабай шикелле, аңа читтән карап тора, үзалдына хәйләле көлемсери.* Г.Әпсәләмов. *Уртак түбә астында уртак балаларның борчу-шатлыклары белән яшәү – кеше гомеренең төп хикмәте, мөгаен, шулдыр.* Г.Әдһәмова

4) Тылсым, могҗиза; кодрәт. *Әйе, бар шул дөньяның хикмәтләре. Исәпләсәң исең китәрлек могҗизалары бар.* Г.Сабиров. *Җил-давыл чыкса, алагаем агачларны пыр туздырып сындырып ташлый, карыш буе зәгыйфь үләннәрнең чәчен генә сыйпап үтә, Ходайның хикмәте.* А.Әхмәтгалиева

5) Нинди дә булса эшнең асыл сере, сәбәбе һәм кызыгы. *Нишләп әле бу Нияз коридор буйлап чатыр чабып йөрүләрен туктатты, нишләп әле әбиләр яткан уң яктагы палата ишеге төбендә генә чуала башлады, дисәм, әһә, хикмәте бар икән.* В.Нуруллин. *Ялгызлык дигән нәрсәнең әнә шундый хикмәтләре дә бар.* Р.Низамиев

**2.** *хәб. функ.* Сәер, искитәрлек, аптырарлык хәл, вазгыять. *Ни хикмәт, киң итеп тын алып шушы җырны көйли башлауга, улым изрәп йоклап та китә.* А.Хәсәнов. *Ни хикмәт, моңарчы тыныч холыклы кебек күренгән Харис тупас, каты бәгырьле кешегә әверелде.* А.Фәләх

◊ **Хикмәте Хода** Сүз арасында гаҗәпләнүне белдерү өчен кулланыла. *Хикмәте Хода, Ардуанның иреннәре калтыраудан туктый.* В.Нуруллин. *Әмма бу юлы... Хикмәте Хода: иң кырыйдагы чүплек савыты эченнән, үч иткәндәй, нәкъ теге чактагыча итеп, кесә телефоны чылтырый иде!* Р.Низамиев

**ХИКМӘТЛӘ́Ү** *ф. сөйл.* Берәр нәрсә эшләү, китереп чыгару; хикмәт чыгару; нәрсәне дә булса башкача, үзенчәлекле, серле итеп эшләү. *Слесарь башың белән, чёрт знает, нәрсәләр хикмәтлисең!* Ш.Камал. *Мәкальләре исә үзенчә хикмәтли: «Алманың асылын корт Гайсә Хөсәенов ашый», – ди.* Г.Хөсәенов

**Хикмәтләп алу** Тиз арада хикмәтләү. *Берәр нәрсә хикмәтләп алырга кирәк икәнен дә аңлыйм инде дә, вакыт җитми бит* ---. Кызыл таң

**Хикмәтләп җибәрү** Бераз хикмәтләү; аз гына хикмәтләү. *Хикмәтләп җибәрсәң, менә дигән уенчык була бу малаеңа.* М.Вәлиев

**Хикмәтләп карау** Булдыра алу-алмавын сынау, тикшерү өчен хикмәтләү; хикмәтләргә тырышу. *Ниләр хикмәтләп карамадым: керәчин белән юдым, кер парашугы белән ышкыдым – рәтләнмәде бичара.* А.Гыйләҗев

**Хикмәтләп кую** Алдан ук хикмәтләү; тиз арада хикмәтләү. *Ай башына хәтле үзегезгә фатир табып хикмәтләп куйсагыз, яхшы булыр иде.* К.Тинчурин

**Хикмәтли башлау** Хикмәтләргә тотыну. *Янгынчылар, футболчылар белән җитез генә ярышкан сыман, машиналарыннан шыбырдашып коелдылар да, озын эчәкләрен сүтә-сүтә, кыр яны судьяларына комачаулап хикмәтли башладылар.* А.Гыйләҗев

**ХИКМӘТЛЕ** *с.* **1.** 1) Серле, тылсымлы; серле итеп эшләнгән. *Мин бу хикмәтле могҗизаның серен белеп китәргә тиешмен.* М.Хәбибуллин. *Карасаз эчендә зәмһәрир суыкларда да боз катмаган хикмәтле күл бар, һәм анда ел саен ике-өч пар үрдәк кыш кышлый иде.* Н.Гыйматдинова

2) Тирән мәгънәле; акыллы, зирәк. *Минем башка сыеп җитмәстәй тирән мәгънәле, эчендә ниндидер бөек серләр яшергән шушы хикмәтле сүзләр мине бөтенләй әсир итте, дулкынландырды.* Г.Бәширов. *Атай, мәрхүм, хикмәтле бер сүз әйтеп калдырган иде.* В.Имамов

3) Гаҗәеп, үзенчәлекле, сокланырлык. *Ә менә теге якта гади кешеләр турында кайгыртып, аларның тормышын җиңеләйтү йөзеннән гаҗәп хикмәтле нәрсәләр уйлап таба бирәләр.* Д.Гыйсметдин. *Һаҗәр күбрәк булмә бизәү белән мәшгуль булды: кулы кәгазьдән әллә нинди хикмәтле сурәтләр ясарга килешеп тора икән.* А.Әхмәтгалиева

**2.** *рәв. мәгъ.* Хикмәт белән; серле итеп. *Касыйм үзенең хикмәтле сөйләшә алуына үзе дә сокланып куйды.* Т.Әйди. *Ул исем, Хәмит Хәеровичның авызыннан чыкканда, нигәдер хикмәтле яңгырый һәм хатын-кызны сихерләү көченә ия була.* Ф.Яхин

**3.** *хәб. функ.* Кызык, гаҗәп, искитәрлек булу; үзенчәлекле булу, мөһим булу. *Шунысы хикмәтле: телебездәге иң кадерле, олы йөрәкле сүзләр, ут-ялкынын тирәнгә, бәгыренә кысып, нибары өч авазга сыйган: Җир. Күк. Кан. Тән. Җыр. Моң. Җан. Рух.* М.Галиев

**ХИЛАФ** *с. гар.* **1.** Ярамый торган, каршы килә торган, тискәре. *Халкыбызның йөз суын түкмик, хилаф эш кылмыйк.* М.Хәсәнов. *Ахры, ул Вәзиханың берәр хилаф ягын белә иде бугай.* Х.Камалов

**2.** *хәб. функ.* Туры килми, килешми; каршы килә. *Бу – табигать законына хилаф. Минем язганнарым тормыш чынлыгына хилаф түгелме?* Ф.Хатыйпов

**ХИЛА́Ф ИТҮ** *ф.* Каршы килү; нәрсәгә дә булса каршы килерлек, килешмәслек, ярамаслык эш эшләү. *Ә инде дуслыкка хилаф итүне җене сөйми.* С.Поварисов. *Җаныңа хилаф иткәнче Җансызга хилафлы бул, Усаллар телгә килгәнче, Син инде ала бар юл.* Ф.Яхин

**ХИЛА́Ф КЫЛУ** *ф. к.* **хилаф итү**. *Кеше үзенең намусына хилаф кылырлык берни эшләмәскә тиеш.* Ш.Галиев. *Әгәр, кенәзләр үзара тыныч тормыш булдыру өчен тырышканнардыр, дип әйтсәк, бу да дөреслеккә хилаф кылу булыр иде.* И.Хужин

**ХИЛАФЛЫК** *и.* Каршылык, каршы килү, туры килмәү. *Хәбир хезмәт абруена берәр төрле хилафлык булмасын дип курка иде, чөнки болай да, һәркемнең агын, карасын дигәндәй, нечкә иләктән үткәрә торган чак.* Х.Камалов. *Мин депутат буларак кына түгел, ЖЭУ начальнигы буларак та әйтәсем килә: латин графикасына күчү кемгә ничектер, ә минем сантехникларыма берниндi хилафлык китермәячәк.* З.Хәким

**ХИЛАФЛЫК ИТҮ** *ф.* Нәрсәгә дә булса каршы килеп эш итү; каршы бару; киртә кую; гомумән каршы булу. *Әмма алар арасында аерма бар: кеше – табигать матурлыгына хилафлык итүче, аны кыручы, туздыручы, утка тотучы, ә сандугач, киресенчә, шул гүзәллеккә мәдхия укучы, ямь өстәүче, аны данлап сайраучы, кешеләр күңелендә изге тойгылар уятырга тырышучы.* С.Поварисов. *Димәк, бу очракта намусына хилафлык итәргә мәҗбүр.* Ф.Галимуллин

**ХИЛАФЛЫ́К КЫЛУ** *ф. к.* **хилафлык итү**. *Яклавыма һич мохтаҗ булмаса да, дөреслеккә хилафлык кыла алмыйм: без бит әле Казан арты туфрагының ташлы гына түгел, ашлы да икәнлеген беләбез; һөнәре барга көн күрсәткән, ил табынына куярлык икмәк, ил күрке булырлык тырыш кешеләр үстереп килгән як ич бу!* М.Вәлиев. *Шул чагында Нурмөхәммәтнең җаны хилафлык кылды: куркуыннан ул дустын ташлап качты.* З.Мурсиев

**ХИ́ЛЕР** *и. ингл.* 1) Филиппин утрауларында хирургия әсбаплары кулланмый гына операция ясаучы яисә гадәти булмаган биоэнергетик сәләт, дога, өшкерү һ.б. ярдәмендә дәвалау сәләтенә ия дип фаразланган табиб; гомумән шундый кеше. *Малай, бу вакыйгадан соң, Аргентина хилерлары турында видеокассета караган.* Ватаным Татарстан. *Казан хилеры беренче авыру янына килеп басты.* Татарстан яшьләре

2) Компьютер уеннарында яисә берничә кеше уйный торган өстәл уеннарында башка уенчыларны һ.б. элекке хәленә кайтара, дәвалый яисә коткара ала торган уенчы

**ХИЛКА** *и. гар. кит.* Җыелып утырган кешеләр түгәрәге. *Аның артында – чалмалы, түбәтәйле, фәсле искеләр тезелешеп утырган хилка.* Г.Тукай. *Суфилар алачыгында күмәкләшеп зикер әйткәндә дәрвишләр хилка ясап утырышалар, уртага шәехне алалар һәм, күзләрен йомган хәлдә, экстаз (җәзеб) халәтенә керәләр.* А.Тимергалин

**ХИМАЯ** *и. гар.* Яклау; кемнең дә булса яклавы, саклавы, канат астына алуы. *Бу кисәкчәләр дә үзләренең тәңресе итеп Аллаһны таныганнар, ә Аллаһ аларга химаясен вәгъдә иткән.* А.Тимергалин. *Сиңа рәхәт, син үз атаңанаң химаясендә үскәнсең.* Р.Батулла

**ХИМАЯ́ ИТҮ** *ф.* Саклау, яклау, канат астына алу. *Һичбер нәрсә аңламаган мужик солдатлар урынына, Русияне дошманнан химая итү өчен, аңлы гаскәриләр җитешәчәктер.* Г.Камал. *Аерым химая итүчеләре – сәүдәгәрләр Фазлулла һәм Әхиярулла.* Кызыл таң

**ХИМАЯ́ КЫЛУ** *ф. к.* **химая итү**. *Венера Ганиева сәнгать әһелләрен өлкәнәйгән чорларында яклар, химая кылыр өчен бер берләшмә төзергә, аңа бүген егәр белән эшләүче җырчы-артистларны тупларга хыяллана.* Мәдәни җомга

**ХИМАЯЛЕ** *с. кит.* Яклаулы, кемнең дә булса канаты астында булган. --- *милләтара әдәби тәрҗемә алмашу химаяле нигезгә корыла.* З.Мансуров

**ХИМАЯЛЕК** *и. кит.* Химаяче эшчәнлеге; химая эше белән шөгыльләнү. *Һәр елның февраль аенда авылыбызда батыр авылдашыбыз призына шушындагы җаваплылыгы чикләнгән «Арбор» җәмгыяте химаялегендә волейбол ярышлары уздырыла.* Шәһри Казан. *Әтәч – гел җиңүгә омтылучы кош, шунлыктан дөньяны яулап алырга теләүчеләр ул химаялек иткән елларда уңышка ирешкән: 1933 елда Германиядә Гитлер канцлер итеп сайланган, Италиядә Муссолини фашистлар партиясен төзегән.* Мәдәни җомга

**ХИМАЯСЕЗ** *с.* **1.** Яклаучысы, саклаучысы булмаган; ярдәм итүчесе булмаган. *Эссе ком сахраларында сусызлыктан хәле бетеп җиргә егылган, ерткычлар алдына ташланган бер химаясез, көчсез кошчык кебек рәнҗетелгән йөрәгемнән өзелеп чыккан: «Ярдәм, ярдәм!» – дигән авазымның соңгы сулышларыма кадәр нинди дә булса бер мәрхәмәт иясенә килеп ирешер өмиде белән, бу мәкаләне милләт нәзаренә тәкъдим итәм.* З.Бурнаши. *Кайсы якка гына колак салма, гөрс тә гөрс җир селкетеп химаясез шәһәрләрне җимерде, тын авылларны яндырды, тузанлы юллар буйлап төркем-төркем качып баручы хатын-кыз, бала-чагаларны кырып йөрде, хәтта ялгыз кешеләрне куып йөрүдән дә тартынмады.* Ә.Еники

**2.** *рәв. мәгъ.* Яклаучысы булмый торып, ярдәм итүчесе булмаган килеш. *Химаясез фирма ачу. Химаясез башкарып чыгу*

**ХИМАЯЧЕ** *и.* Яклаучы, саклаучы, канат астына алучы; кемнәрнең дә булса мәнфәгатьләрен кайгыртучы. *Машина китеп баргач, бөтен колониягә һәм ятим малайларга бердәнбер химаяче булып калган Василий Фомич тимер капканы үз кулы белән дөмбердәтеп яба, хәтта бикләп куя.* А.Тимергалин. *Сезнең Аллаһтан башка химаячегез дә, ярдәмчегез дә юк.* Казан утлары

**ХИМАЯЧЕЛЕК** *и.* 1) Химаяче булу хәле. *Хатын-кыз химаячелеге сезнең ирлек горурлыгыгызга тисә, язып барырсыз.* Р.Батулла

2) Химая итү эшчәнлеге. *«Россия – ислам дөньясы» химаячелегендә уздырылган бу мәҗлеснең («Түгәрәк өстәл»нең) көн тәртибендәге төп мәсьәлә Ч.Айтматов мирасын мәдәниятләр бағланышы яссылыгында карау иде.* Мәдәни җомга. *Мәгълүм булганча, Республика яшьләр эстрада сәнгате телевизион проекты Татарстан президенты химаячелегендә оештырыла.* Мәйдан

**ХИМЕ́РА** *и. гр.* 1) Борынгы грек мифологиясендә: авызыннан ут чыгара торган арыслан башлы, кәҗә гәүдәле, елан койрыклы мифик зат. *Бу җирләрдә арыслан башлы, кәҗә гәүдәле, аждаһа койрыклы, ут төкерүче Химера яшәгән, ди.* Сөембикә

2) *биол.* Генетик яктан төрле төр күзәнәкләрдән гыйбарәт организм. *Еш кына химераларны декоратив максатларда кулланалар*

3) *зоол.* Химерачалар семьялыгыннан тропик, урта пояс диңгезләрендә яшәүче кыска түгәрәгрәк танаулы балык. *Химералар Һинд, Атлантик һәм Тын океан суларында яшиләр, шулай ук аларны 1000–2500 метр тирәнлектәге диңгезләрдә дә очратырга мөмкин.* Хайваннар дөньясы

4) *арх.* Готика стилендәге биналар түбәсенә ниндидер аерым кимчелекне гәүдәләндерүче буларак урнаштырылган хыялый җанвар сыны

5) *күч.* Чынга ашмаслык идея, сәер фантазия, абсурд. *Аңаирешү юлындагы хезмәт әллә нинди сихри көчкә, әллә нинди химерага һәм шул тискәре зарядлы ясалма һәм уйдырма нәмәстәкәй кумирга әйләндерелә икән, бу инде батырлык түгел, шәхес культына җир эшкәртү, шул туфракны химик әзерләү генә.* М.Гайнетдинов. *Аңлатып торуның кирәге бар микән «химера» сүзенең татарча мәгънәсен? «Тузга язмаган ахмаклык» кебегрәк аның мәгънәсе.* Ф.Баттал

**ХИМЕ́РАЧАЛАР** *и. зоол. күпл.* Химерасыманнар отрядыннан тропик, урта пояс диңгезләрдә яшәүче түгәрәгрәк формадагы кыска танаулы химераларны һәм гидролагларны берләштерә торган семьялык; *русчасы:* **химеровые**

**ХИ́МИК** I *и. лат.* 1) Химия белгече; химия белән шөгыльләнүче галим. *Араларында химиклар да, физиклар да, математиклар да, астрономнар да була.* Р.Мостафин. *Мәрьям эскизы буенча анда кулына колба тоткан егет сурәте булып, биредә химиклар яшәгәнен күрсәтеп торырга тиеш иде.* М.Маликова

2) Химия сәнәгате хезмәткәре. *Шуннан бирле һәр җәй саен бу коллектив авылларга, химиклар янына, КамАЗга бара.* Ч.Бәхтиярова. *Татарстанның яңа химиклар каласы химкомбинаттан шактый ерак урнашкан икән, монда химия төтеннәре килеп җитми.* Казан утлары

3) *сөйл.* Химия укытучысы. *Ә инде чәчен чәчкә пединститут тәмамлаган берәр тарихчы, математик, химик, географ белән бәйләсә, нинди перспектива көтә?* А.Хәсәнов

**ХИ́МИК** II *с.* 1) Химиягә мөнәсәбәтле, химиягә бәйләнешле булган; химия кулланылган, химия матдәләре кулланылып башкарыла торган. *Хәзер исә авыр һәм катлаулы җир катламнары белән эш итәргә, элеккеге «үле» ятмаларга җан кертү өчен, аларны термик һәм химик ысуллар белән эшкәртү кебек яңа алымнарны киң кулланырга вакыт җитте.* М.Зарипов. *Киләсе елда химик җитештерүгә, урман эшкәртүгә, машина төзүгә бәйле берничә мегапредприятие төзи башлаячакбыз.* Кызыл таң

2) Химия өлкәсенә караган, химия фәне өйрәнә торган. *Һәм уртага ике егетне чакырып, химик элементлар турында әңгәмә корырга тәкъдим итте.* М.Маликова. *Кем белә, киләчәктә кем тарафыннан да булса аның суы зур химик анализ үткәрелеп тикшерелер дип уйлыйм.* Р.Зарипов

3) Химия юлы белән эшләнгән, химик препаратлардан җитештерелгән. *Бала чактан ук авыл исенә, кырболыннар, мәһабәт урманнар исенә күнеккән борынга бөтенләй үзгә, химик матдәләр исе килеп бәрелде.* Җ.Дәрзаман. *Татарстан җитәкчеләре хәзер Минзәлә төбәгендә зур химик ашламалар комплексы кору турында сүз алып бара.* М.Әхмәтҗанов

**ХИМИКА́ЛИЯЛӘР** *и. нем. күпл. махс. к.* **химикатлар**

**ХИМИКАТЛАР** *и. күпл. махс.* 1) Химик препаратлар, реактивлар һәм химик эшләнмәләр. *Аннары, күпчелек өлеше судан торган нефтьне бераз чистарту нияте белән, нефть катламына химикатлар җибәрә башладылар.* Ф.Яруллин. *Шуңа күрә химия заводында, капчыкка төялгән химикатлар арасында, калькулятор төймәләре шыкылдатып кына утыруны җене дә сөйми Зиннур Миңнуровичның, моны үзе өчен артык вакчыллыкка да саный.* Җ.Юныс

2) Химик юл белән җитештерелеп, көндәлек тормышта кулланыла торган эшләнмәләр. – *Халык чистарды хәзер, керне химикатлар белән генә агарта,* – *ди ул, эш ансатлашуга сөенеп.* Ш.Галиев. *Төрле химикатлар белән чәчләрен көйдереп бетерәләр дә ярым пеләшкә әйләнәләр!* А.Гыйләҗев

**ХИ́МИЯ** *и. лат.* 1) Матдәләрнең составларын, эчке төзелешләрен, үзенчәлекләрен һәм бер матдәнең икенче матдәгә әверелүен өйрәнә торган фән. – *Биологияне, химияне яхшы белгәнгә түгел, аз сүзле булган өчен мине лабораториягә алдылар,* – *дип көлгәли ул.* А.Гыйләҗев. *Абдуллин Илдар Габделфәрт улы – галим, химия фәннәре докторы.* Г.Мөхәммәтшин

2) Әлеге фән нигезләрен өйрәтә торган предмет, дәрес. – *Менә монда,* – *диде ул, газетага кулы белән сугып,* – *инженер-химик кирәк, дигәннәр, менә монысында, химиядән укытучы кирәк, дип язганнар.* А.Алиш. *Химиянең китабы да, дәфтәре дә килмәгән икән.* А.Әхмәтгалиева // *сөйл.* Шул предмет буенча дәреслек. – *Химияне онытып калдырганмын бүген, синекен алып торыйм әле,* – *дип елмайды партадашым.* Мәйдан

3) Әлеге фәнгә нигезләнеп, төрле органик һәм органик булмаган матдәләрне эшкәртү, шулардан төрле химик эшләнмәләр җитештерү сәнәгате; әлеге сәнәгатьнең бер тармагы; шундый завод, фабрика, предприятие. *Рәшат башлаган күңелсезлектән соң, мин Казаннан китеп торырга карар иттем. Яңа якларга. Я нефтькә, я химиягә.* А.Гыйләҗев. *«Өченче илләр»дәге кебек ук, төп басым чимал сатуга, химияне үстерүгә һәм армияне ныгытуга ясала.* Р.Хәкимов

4) *җый. сөйл.* Химик, гомумән, табигый булмаган кушылмалар, материал, чимал һ.б.ш.лар. *Министр очырта тора, утлы төпчекләр литерлы поезд вагонының яртылаш химиядән генә торган почмакларына барып-барып төшәләр.* А.Гыйләҗев

5) *җый. сөйл.* Авыл хуҗалыгында, бакчачылыкта һ.б.ш. тармакларда кулланыла торган химик юл белән эшләнгән препаратлар; ашлама; дару. *Сугару киң кулланыла, әмма бернинди химия дә кертелми.* Р.Фәизов. *Берничә ел элек Русия халкы Көнбатыштан килгән җиләк-җимешкә, азык-төлеккә ябырылды, үзенекеннән йөз чөерде, хәзер читтән килгән ашамлыкларның химиягә, тагын әллә ниләргә манчылганын аңлап, үзенекен сагына башлады.* Т.Галиуллин

6) *сөйл.* Дәвалауның химик методлары; яман чирләрне дәвалауда кулланыла торган бик көчле дарулар, препаратлар. *Казаннан, рак авырулары шифаханәсеннән, чираттагы «химия белән бомбардировкадан» кайтышыбыз.* А.Хәсәнов. *Химия алганнан соң чәче коелып бетеп, ап-ак чырайлы мәрмәр таш сынга охшап калган хатынын күргәч, чирканып карап торган йөзе хәзер дә хәтерендә.* З.Кадыйрова

7) Көндәлек тормышта, бигрәк тә юу, чистарту, агарту кебек эшләрдә кулланыла торган, химик юл белән ясалган матдәләр. *Ыгы-зыгылы һәм пычрак һавалы шәһәрдән, хлорлы судан, көнкүреш химиясен куллланудан балаларны берничә атнага гына булса да азат итәргә кирәк.* Өмет. *Экологик яктан чиста продукт кына ашап калмыйча, өй җыештырганда да мөмкин булганча химия кулланмаска кирәк.* Шәһри Казан

8) Химик корал. *Ярый, химия кулланып һава сугышы да булды, ди.* А.Толстой

9) *сөйл.* Чәчне химик юл белән бөдрәләтү ысулы. *Әлә-лә, бөдрәләрем тurая, име. Химия ясаттырырга, име.* Н.Гыйматдинова. *Чәч кистереп, җиңелчә*

*химия дә ясатып кайткач, бигрәкләр дә чибәрләнеп китте.* З.Мансур

10) *сөйл.* Исертә, аңгырайта, үзәк нерв системасын зәгыйфьләндерә торган матдә; наркотик. *Казан яшүсмерләре хәзер шушы химияне кулланып кәефләнә икән.* Безнең гәҗит

**ХИ́МИЯЛӘШТЕРҮ** *ф.* Химия фәне казанышларын, химик эшләнмә, химик юл белән эшкәртү методларын техникага, сәнәгать өлкәсенә һәм авыл хуҗалыгына кертү, куллана башлау. *Фатих Хәлил улы Минушев – райбашкарма председателе, Арча, Әтнә якларын химияләштергән галим.* Г.Ахунов. *Билгеле инде, без газиз җиребезне химияләштерергә тотындык.* Ж.Дәрзаман

**Химияләштерә башлау** Химияләштерергә тотыну. *Егерме-утыз ел элек химияләштерә башлаган иделәр – менә нәтиҗәсе ---.* Кызыл таң

**Химияләштереп бетерү** Тәмам химияләштерү; барысын да һәм күп итеп химияләштерү. *Бөтен нәрсәне тәмам химияләштереп бетерделәр инде.* М.Садыйков. *Бүген без авыл хуҗалыгы белән азык-төлек промышленностен гына түгел, гомумән, бар нәрсәне дә: торакны, җиһазны, кием-салымны, савыт-сабаны химияләштереп бетердек.* Татарстан яшьләре

**Химияләштереп җибәрү** Тиз арада химияләштерү; бераз химияләштерү. *– Башкалар кебек, син дә химияләштереп җибәр, кемнән куркасың? – диде ул дорфа гына.* Р.Зарипов

**ХИ́НА** *и. сөйл. к.* **хинин**. *Хатыны дарулар, хиналар да биреп маташа иде.* Ш.Камал. *– Тагы хина эчтеңме? – дип төбәлде комбат аңа, йомшак тавыш белән.* Х.Камалов

**ХИ́НА АГАЧЫ** *и. бот.* Мареначалар семьялыгыннан кабыгыннан буягыч матдә алына торган мәңгеяшел тропик агач; *русчасы:* **хинное дерево**. *Хина агачының кабыгы тропик илләрне яулап алган бик күп колонизаторларның – голландиялеләрнең һәм инглизләрнең тормышларын коткарып калган.* Н.Верзилин. *Африкада һәм Австралиядә үсә торган үсемлекләр, мәсәлән, пальма, сәрби һәм шешә агач белән беррәттән, аларның Көньяк Америкага гына хас төрләре – каучуклы гевея, какао һәм кабыгыннан дару ясый торган хина агачлары бар.* Материклар һәм океаннар географиясе

**ХИНИН** *и. нем. махс.* Хина агачы кабыгыннан әзерләнә һәм медицинада кулланыла торган ак төстәге бик ачы порошоксыман дару. *Җүнләп кирәге булмаса да, карт провизордан, бөтенләй ят-чит тавыш белән, үзенең актык акчасына хинин, аспирин сорый.* Г.Ибраһимов. *Ә 1936–1937 елларда үзенең төп белгечлегеннән, ниһаять, кыска гына вакыт рәсми төстә файдаланып ала: Сәмәрканд өлкәсенең Жизак шәһәрендә чәчәк салучы (оспопрививатель) һәм хинин белән дәвалаучы булып эшли.* Р.Әмирхан

**ХИНКА́ЛИ** *и. груз.* Камыр эченә тартылган ит, суган, тәмләткечләр салып, өстен бөреп ябыштырып, суда пешерелә торган, эре пилмәнгә охшаш кайнар ашамлык (аеруча Алгы Азия һәм Кавказ халыкларында популяр). *Автовокзал биләмәләрен карап йөри торгач, арт якта ул шашлычныйга барып төртелде, шунда ук кулдан гына хинкали да сата иделәр, анысын, мөгаен, якындагы йортларда пешерәләрдер инде.* Р.Мирхәйдәров

**ХИ́ППИ** *и. ингл.* 1) 1960 елларда АКШнда барлыкка килгән, табигый матурлыкка, чисталыкка, ирекккә өстенлек биргән фәлсәфә һәм субкультура; шундый принциплар белән яши торган яшьләр агымы. *Хиппи агымы шулкадәр популяр булган ки, хәтта аларның аерым шәһәрчекләре дә барлыкка килгән.* Ватаным Татарстан. *Яшьләрнең һәртөрле субкультуралары (готлар, эмо, рокерлар, хиппи), музыка акырту, киенү үзенчәлекләре, виртуаль социаль челтәрләрдә аралашу – болар барысы да яшь кешенең җәмгыятьтәге оригиналь позициясен күрсәтүгә омтылышы.* Сөембикә

2) Шул субкультура вәкиле. *Хиппилар иске-москы, тузган чалбар киюне затлы киемнән артыграк күрәләр!* И.Юзеев. *Болар барысы Стрит урамында, элек ул урам гөрләп торган, диләр, --- соңыннан бу урамда хиппилар күренә башлаган, алар атаманлык итәргә керешкәннәр, халыкка ул ошамый, урам инде элекке данын югалта бара.* М.Мәһдиев

**ХИРКА** *и. гар. иск.* Тупас тукымадан тегелгән озын җиңле, тезләргә кадәр төшкән ирләр киеме. *Мәсәлән, суфыйчылык юлбашчысы үз хиркасын алмаш булып калачак мөридәнә бирү традициясе булган, һәм бу күренеш әлеге поэмада да бар.* Р.Мәрдәнов. *Хинг Ши, бераз уйланып торганнан соң: – Хирканың киңлеге ярты иң.* Яңарыш

**ХИРУРГ** *и. гр.* Хирургия тармагында махсуслашкан табиб. *Ялдан соң операция ясаячак хирург аның белән тагын бик озак сөйләште, эчләрен баскалап карады.* Ф.Садриев. *Аннары, менә Сез, мәсәлән, дипломын акчага сатып алган надан хирург пычагы астына ятарга риза булыр идегезме?* Р.Вәлиев

**ХИРУ́РГИК** *с.* 1) Хирургиягә мөнәсәбәтле; хирургиягә караган. *Аннары савыктыру өчен хирургик ысулны сайлап алды һәм бөтен осталыгын җигеп эшкә кереште.* Т.Әйди. *Беренче баласын ярып алган аналарны икенче йөклелектә дә хирургик юл көтә.* Ирек мәйданы

2) Хирургиядә кулланыла торган; операция вакытында файдаланыла торган. *Без, хирургик микроскоплар юк чакта да, Ходаяровның гаҗәеп оста операцияләр ясавына, аларга җентекләп әзерләнүенә соклана идек.* Т.Әйди. *Ул кулларда – куәтле краннар, --- хирургик инструментлар, балалар уенчыклары, җылы шәлләр.* Кызыл таң

3) Хирургия юлы, чаралары белән башкарыла торган. *Хирургик операциядән соң яралары бик озак төзәлә.* М.Вәлиев. *Ябыгу өчен чыгарылган медицина препаратларын исә 15 яшьтән генә кулланырга рөхсәт ителә, яшүсмергә хирургик операцияләр турында инде уйлыйсы да юк.* Ватаным Татарстан

**ХИРУРГИ́Я** *и. гр.* 1) Медицинаның хирургик манипуляция ясап дәвалана торган авыруларны өйрәнә һәм операция ясау ысулларын, чараларын, тәртибен эшли торган тармагы. *Кайчандыр хирургия өчен тыелган, хирург пычагы кагылырга рөхсәт ителми торган чикләр бүген әллә кайда артта калдылар инде.* Г.Әпсәләмов. *Хәзер медицина көчле, хирургия могҗизалар тудыра, йөрәккә кадәр күчереп утырталар.* Ф.Яруллин

2) Әлеге фән нигезләрен өйрәтә торган предмет. *Институтта ул хирургия кафедрасын алып бара.* Г.Әпсәләмов // *сөйл.* Шул предмет буенча дәреслек. *Кулыма «Хирургия» китабын алып, «Панариций» темасын укып караган идем, телсез-өнсез калдым.* Н.Фәттах

3) Авыруны, чирне операция ясап дәвалау. *– Моңа лазер хирургиясенә күчү нәтиҗәсендә мөмкин булачак, – дип аңлата үзәкнең офтальмология бүлеге мөдире Искәндәр Бәширов.* Т.Нәҗмиев. *Чынлыкта Алмаз аңа үзенең хирургиягә, медицинага бирелгәнлеге белән ошады.* Ә.Сәйфетдинов

4) Хастаханәнең хирургик операцияләр ясала, хирургик ысуллар белән дәвалау алып барыла торган бүлеге. *Кон-*

*сультациягә яңадан хирургиянең дежур врачы Аллаяровны чакыралар.* С.Сөләйманова. *Фаилне хирургиягә җилкәсен тегәргә алып менеп киттеләр.* В.Гали

**ХИРЫС** *и. гар.* **1.** 1) Нәфес, комсызлык, комагайлык, саранлык. *Бергә башлаганнар әллә кайда югалып калды: кайсы эчеп, кайсы, хирысын тыя алмыйча, «кәкре» эшләр белән абруен югалтты.* И.Сабиров. *Хирысың аз булса, шатлыгың күбрәк.* Безнең мирас

2) Көчле теләк, омтылыш. *Һәркем аны үзе өчен яңадән яза. Табигате сораганча, хирысы таләп иткәнчә...* Т.Галиуллин. *Европага килү теләге, хирысы шул кадәр көчле ки, җирле халыкның якты чырай белән каршы алмавы да туктатмый аларны.* Шәһри Казан

**2.** *с. мәгъ.* 1) Комсыз, комагай, кызыгучан, нәфесле. *Безнең әни малга хирыс кеше түгел иде, нинди авыр сугыш елларында да ул әйберләрне исенә дә алмады.* Ә.Сафиуллин

2) Нәрсәгә дә булса көчле омтылышы булган, сәләтле, оста, һәвәс. *Сәүдәгә һәм телләр өйрәнүгә хирыс халык буларак, яһүдләр тиз арада Хазарстанның төп халкын тәшкил иткән төркиләр белән туганлашып китәләр.* М.Хәбибуллин

**3.** *хәб. функ.* 1) Һәвәс, оста булу. *Элек болай ук түгел иде, хәзер яшьләр киемгә бик хирыс.* Г.Әпсәләмов. *Безнең авыл халкы бер-берсенә кушамат куярга хирыс.* Г.Шәйхиева

2) Нәфесле булу. *Борчылуым шуннан иде: Халитнең мин укырга бик хирыс булмавын, фәнни тармакны бөтенләй дә күз алдына китерә алмавын, бик сай фикерле булуын яхшы беләм.* Н.Акмал. *Ләкин шул ук вакытта биредә кешеләрнең акчага бик хирыс икәнен атлаган саен тоеп торасың.* Р.Вәлиев

**ХИРЫСЛЫ** *с. ялг. к.* **хирыс 2.** *Очрашкан кешеләр арасында шәхси мәнфәгатьләрен башка бөтен эшләрдән дә әһәмиятлерәк дип белгән кайбер хирыслы адәмнәр бар иде.* Г.Исхакый. *Хәер, бу хакта шагыйрь Сабир Абдуллинның истәлекләрендә дә беркадәре материал табарга мөмкин: «Хәмзә бик яшьли үк гыйлемгә бирелеп, укуга хирыслы кеше иде».* Л.Мәхсүмова

**ХИРЫСЛЫК** *и.* Хирыс булу сыйфаты; һәвәслек, омтылучанлык. *Каян килгән ул сиңа шулкадәр акчага, байлыкка хирыслык?* Г.Галиева. *Илгизәрлек, сәяхәтләргә хирыслык адәм баласының холкында шул.* Р.Мулланурова

**ХИС** *и. гар.* 1) Организмның үзенең физик хәленә карата барлыкка килгән реакциясе, тою сәләте. *Көчле ачыгу хисе һәм бертуктаусыз ашыйсы килү, ләкин шул ук вакытта ябыгасы килү теләге, үз-үзеңә ышанмау, үзеңне симез итеп хис итү – болар булимия симптомнары.* Кызыл таң. *Карале, бу эт тә минем кебек сусау хисе белән яна бит, дип, әлеге этне бик җәлли.* Шәһри Казан

2) Чынбарлыктагы күренешләргә, вакыйгаларга карата барлыкка килгән психик халәтнең чагылышы. *Шул чакта Назимовны әллә нинди бер хис биләп ала: әллә намусы кыйнала, әллә үз-үзенә ачуы килә.* Г.Әпсәләмов. *Мөселман кешесенең хайванга мәрхәмәтле булуын күреп соклану хисе кичердем.* А.Тимергалин

3) Кешенең эчке психик, рухи халәте; чынбарлыктагы тәэсирләргә җавап бирә алу сәләте. *Олыгая-олыгая, адәм баласының сөенү хисе тоныгая, диләр.* Н.Гыйматдинова. *Гаҗәп хәл: минем күңелемдә берниндн икеләнү, борчылу, курку хисе калмады, алай гына да түгел, бөтен гәүдәмне, баш миемне ниндидер бушлык сырып алды.* А.Әхмәтгалиева

4) Эчке дулкынлану, күңел ярсуы, дәрт, омтылыш. *Моңы искитәрлек булмаса да, хис белән җырлагач, җыры йөрәккә барып җитә.* Ф.Яруллин. *Аңлашылмаган хисләр ташкыны Рәйханны кабаланырга мәҗбүр итте, ул шушы мизгелдә үк, мине шул кыз белән таныштыр әле, дип, Хәлимгә ябышты.* З.Мурсиев

5) Әйләнә-тирәдәге чынбарлык күренешләрен, сәнгать әсәрләрен һ.б.ш.ны аерым бер төрле кабул итә алу сәләте. – *Укымышы да булмаган Лотфуллаларга мондый матурлык хисе кайдан килгән? – дип сорады ул һәм үзе үк җавап та бирде: – Халык күңеленнән!* Г.Әпсәләмов. *Зур гәүдәле, көрәк куллы Галләмдә юмор хисе бардыр дип башына да китерми иде Барый, карт шаяртырга да оста икән.* З.Хөснияр

6) Үзеңнең башкаларга мөнәсәбәтеңне, алар белән бәйле булуыңны, иҗтимагый хәлне һ.б.ш. аңлау, төшенү. *«Менә ичмасам минем халкым!» дигән горурлык хисе күңелдә үзеннән-үзе туа!* А.Хәсәнов. *Үзенең гаять зур тырышлыгы, максатка омтылучанлыгы, хезмәтен яратуы, хезмәтенең нәтиҗәлелеге өчен олы җаваплылык хисе аны районыбызның иң тәҗрибәле укытучылары сафына күтәрде.* Г.Мөхәммәтшин

**ХИСАБЫНА** *бәйл.* 1) Кемнең дә булса акчасына, исәбенә; нинди дә булса чыганак, кеше исәбеннән. *Фая күптән инде укуын ташлаган, бүлмәдәшләре хисабына яшәп яткан икән.* Г.Бәйрәмова. *Мин бит патша хисабына яшәгән рәссам түгел, үз көнемне үзем күрәм.* Н.Гыйматдинова

2) Берәр нәрсә урынына, бәрабәренә, исәбенә (алу, файдалану, эшләү һ.б.ш. тур.). *Мәкаләне мин төннәр утырып, йокы хисабына яза идем.* М.Мәһдиев. *Көндезге, кичке аш хисабына артистлар, җырлап, уйнап, шигырь сөйләп, публиканың күңелен ачарга тиеш булалар.* Р.Батулла

3) Кемнең дә булса исеменә, адресына карата. *Габдулла моны үз хисабына кабул итте.* Ә.Фәйзи. *Кыз елмаюны үз хисабына алды һәм елмаюга елмаю белән җавап кайтарды.* Г.Кутуй

**ХИСАБЫННАН** *бәйл.* Нинди дә булса чыганактан (алып тору, файдалану, куллану һ.б.ш. тур.). *Аванс хисабыннан ике йөз илле сум акча яздырыгыз.* Р.Вәлиев. *Чыгымнарның бер өлеше бюджет хисабыннан булыр, районнарга хат җибәрербез, шәпләп оештырырлар!* К.Кәримов

**ХИСАП** *и. гар.* 1) Берәр нәрсәнең гомуми саны, микъдары яки шул микъдарны билгеләү нәтиҗәсе. *Борынгы төркиләр яшәешләрен һәм вакыт хисабын «дөнья яратылган көннән» башлаганнар.* Г.Дәүләтшин. *Түшәм күзләп яткан көн һәм төннәрнең хисабын югалтып, саннарында адашырлык гомер узган ла!* Г.Әдһәмова

2) Нәрсәне дә булса санау, исәпләү эше. *Ләкин дөньяда «вазифаи бурыч» дигән нәрсә бар: елап туйгач, кызарган дымлы күзләрен яулык очларына сөртеп, ул янә хисап эшенә ябышты.* Н.Әхмәдиев. *Хәер, хәзерге вакытта мондый катлаулы хисап эшләрен тиешле программа белән тәэмин ителгән компьютер ике-өч минутта әйләндереп чыгара ---.* А.Тимергалин

3) Математиканың исәпләргә өйрәтә торган тармагы; арифметика. *Хисап дигән фәнне каян белсен инде ул мескен ай!* З.Хөснияр. *Хисаптан бишлеләр алган көнне стенадагы календарьның тагын бер бите кызылга буялды.* Г.Гыйльманов

4) Акча белән бәйле мөнәсәбәт, исәп-хисап, алыш-биреш, түләү. *Мин чәйне җыйдырып, пароход хадиме белән хисабымны бетердем.* Ф.Әмирхан

5) Нәрсәнең дә булса саны, исәбе турында язу; керем һәм чыгымны исәпләү нәтиҗәсе; йомгагы. *Ул өзек кәгазь алып килеп, Шәмсигә тулы бер хисап күрсәтте.* Г.Исхакый. *Мин тиз-тиз генә кием кибетебезне тикшердем дә, хисап кенәгәсен алып, базарга чаптым.* З.Хәким

6) Эшләнгән эш турында отчёт. *Колхоздан – район, районнан Казан хисап таләп итә.* Н.Әхмәдиев. *Минә, кайткач, хисап ясап йөрим.* А.Хәмзин

7) *сөйл.* Берәр нәрсә хакында кыскача аңлатма, бәяләмә, нәтиҗә. *Алып кайткан сызымнарын өстәлгә җәеп салып: – Менә бусы йокы бүлмәсе, монысы ашханә, ял бүлмәсе, балалар бүлмәсе, сейф, – дип хисап биреп бара.* Г.Гыйльманов. *Ничек яшәвем турында хисап, дисең инде син...* Д.Каюмова

8) *сөйл. к.* **счёт** (*2 мәгъ.*). *Мин бүген ук Автозавод банкында махсус хисап ачтырам.* В.Имамов

9) *дини* Кыямәт көнендә гөнаһлар өчен җавап бирү. *Гыймран бин Хөсәеннән килеп ирешкән бер хәдистән Пәйгамбәрнең: «Кайберәүләр Хисап көнендә Мөхәммәд Пәйгамбәр үтенече белән җәһәннәмнән чыгарылыр», – дигән сүзләре билгеле.* А.Тимергалин

◊ **Хисабы юк** Бик күп, санап бетергесез, исәпсез-хисапсыз. *Ләкин һаман да аларның өстендә булган куркынычларның хисабы юк.* Г.Бубый. *Ишегалдында хайванның, кош-кортның хисабы юк.* И.Юзеев. **Хисап бирмичә (бирмәстән)** Уйламыйча; механик рәвештә, кызып китеп. – *Китәрбез!* – *дидем мин, үз сүземә хисап бирмичә генә.* М.Җәлил. *Бану гына, ни өчен болай эшләгәненә хисап бирмичә, адымнарын акрынайтты, аннары бөтенләй туктап калды.* А.Вергазов. **Хисапны өзү** 1) Араны өзү, кем яки нәрсә белән булса да бәйләнешне, мөнәсәбәтләрне туктату; 2) Расчёт ясау (алу), акча мөнәсәбәтләрен өзү. *Риза бул, Котлыбикә. Без хисапны өздек.* Т.Гарипова. *Андый очракта кулдан акча бирми генә хисапны өзү кирәк.* Татарстан яшьләре; 3) Үч алу, үзеңә дошман булган кешене юк итү. *Мин бүген качкыннар белән хисабымны өзәчәкмен.* Ф.Бурнаш. **Хисаптан чыгарылу** *к.* **исәптән чыгарып ташлау**. *Шуны әйтергә кирәк: заманнар үзгәргән саен шәригать хөкемнәрендә дә, әдәптә дә кайбер кануннар хисаптан чыгарыла, яңалары мәйданга килә тора.* Ф.Яхин. **Хисаптан чыгарып ташлау** *к.* **исәптән чыгарып ташлау**. *Гомер дисбесенә теркәлгән елларның һәркайсы газиз, һәркайсы үз, аларның берсен дә хисаптан чыгарып ташлап булмый.* И.Әхмәтҗанов. **Хисаптан чыгу** Онытылу, мөһимлеге, әһәмияте, кадере югалу. *Туган авыл дип лаф орма, алар өчен син юк инде. Күптән онытылган, хисаптан чыккан.* Р.Мөхәммәдиев

**ХИСА́П ИТҮ** *ф.* 1) Нәрсәнең дә булса күләмен, санын һ.б. исәпләү; санау. *Өч-дүрт көне үткәч кайта җыеннан әйләнеп, Хисап итеп карасалар, бурычка беткән бәйләнеп.* К.Насыйри. *Ул вакытларда мөселманнар егерме биш миллион чамасы дип хисап ителгән.* Г.Камал

2) Фикердә булу, уйлау, санау, исәпләү. *Ул аны русларның иң гали мөхәррирләреннән саный, иң зур психологларыннан хисап итә иде...* М.Хәсәнов

**ХИСА́П КӨНЕ** *и. дини* Кыямәт көне, кубарылу көне. *Хисап көне килгәч, мине вә атамны вә мөселман кардәшләремне ярлыка.* М.Хәбибуллин. *Хәсбикамалым минем, үлчәвемнең икенче башы – үлчәү ташы, ахирәттә Хисап көнендә мине яклап таныклык бирергә тиешле җан иясе икән бит.* Л.Ибраһимова

**ХИСАПЛАМА** *и.* Хисаплап чыгарылган нәтиҗә; исәп-хисап. *Төгәл хисаплама*

**ХИСАПЛА́У** *ф.* 1) Санау, исәпләү, исәбен билгеләү, исәбен алу. *Малайларның атларын кая бастырып тарттырырга кирәклеген чамаладык, исәпләдек, хисапладык.* А.Гыйләҗев. *Күңеленнән ниләрдер хисаплый, үлчи иде кебек ул.* Р.Мөхәммәдиев

2) Санап чыгару; нәрсәне дә булса исәпләп чыгарып билгеләү. --- *Үзәк Комитет секретаре ялгап алып китте: – Шулай булгач, без бирелә хисапладык, итен дә, сөтен дә күбрәк сатачаксыз.* Ф.Садриев. *Ак бабай нидер хисаплады да, һич шикләнмичә, кодлы йозакның уң күзенә ике тапкыр басты.* Р.Нуруллин

3) Үзеннән алда килгән сүзләр белдергәнчә санау, уйлау; кем яки нәрсә дип уйлау, исәпләү, билгеле фикердә булу. *Үзен эшкә тотынган хисаплый.* Ф.Әмирхан. *Үзен татар дип хисаплаган кеше башына шундый түгәрәк түбәтәй кигән.* Б.Рәхимова

**Хисаплап алу** Кыска гына вакыт эчендә хисаплау. *Бай да, күп файданы күргәч, бик кәефләнеп, биш мең дәнә алтынның хәзерге базарда утыз җиде мең ярым сум, өч мең көмеш өч мең сум – җәмгысы кырык мең биш йөз сум булачагыны «зирәк»леге аркасында тиз генә хисаплап алды.* Г.Камал. *Һәм үз-үзенә ышанмады, тагы бер мәртәбә хисаплап алды.* Ф.Хәбибуллин

**Хисаплап бетерү** Хисаплауны тәгәлләү. *Әй Идел, Идел! Синең тәнебезгә һәм рухыбызга биргән бөтен игелекләреңне әйтеп бетерерлек сүз, хисаплап бетерерлек сан бар микән?!* Р.Фәйзуллин. *Кызганычка каршы, бабам йорт түбәсен ябуны төгәл хисаплап бетермәгән.* Р.Зарипов

**Хисаплап йөрү** Гел, һәрвакыт хисаплау; озак вакыт хисаплау. *Әле сәхнә ачылганга кадәр үзен милләтпәрвәр, уен остасы дип хисаплап йөргән Хисами хакыйкатькә төшенә: ул профессиясе белән генә түгел, рухи яктан да артист түгел, гади бер приказчик икән ләбаса!* Д.Заһидуллина

**Хисаплап карау** Хисапларга тырышу, хисаплау тәҗрибәсе ясау. *Сез аларга тагын бер кат төгәлрәк итеп хисаплап карарга кушыгыз.* Р.Вәлиев. *Үзенең узган юлын, маршрутын, тизлеген якынча чамалап, галушның очу траекториясен хисаплап карады.* Җ.Юныс

**Хисаплап килү** Күптәннән бирле даими рәвештә хисаплау. *Биш ел хисаплап киләм, тик нәтиҗәсе син көткәнчә түгел.* И.Гази

**Хисаплап кую** Алдан хисаплау, хисаплап әзер итү. *Хаты ничә көн эчендә барып җитәр дә, ничә көн эчендә җавап килеп җитәр – ул инде боларны көне-сәгате белән диярлек алдан ук хисаплап куйды.* Р.Мөхәммәдиев. *Безгә бу җәһәттән шәхси бизнестан сабак алырга кирәк, алар хезмәткәрне алмаштыруга караганда кабат әзерләүнең арзангарак төшүен күптән инде хисаплап куйдылар.* Шәһри Казан

**Хисаплап ташлау** *сөйл.* Тиз арада хисаплау. *Көлдермә инде, алай гына мин дә хисаплап ташлыйм аны ---.* М.Вәлиев

**Хисаплап тору** Әле, хәзерге вакытта хисаплау; әледән-әле, даими хисаплау. *Киләсе көз уңышын җыйгач, өйне бераз зурайта төшәргә, тагын бер почмак өстәргә, чамасы җитә калса, ак мунча тәвәккәлләргә хисаплап тора иде.* А.Хәсәнов. *Таза-таза ирләр, колак артына карандаш кыстырып, күпме икмәк кайтканны, киткәнне хисаплап торды.* Р.Мөхәммәдиев

**Хисаплап чыгу** Барысын да хисаплау; һәрберсен бер-бер артлы хисаплау

**Хисаплый бару** Һәммәсен эзлекле рәвештә хисаплау

**Хисаплый башлау** Хисапларга керешү. *Әгәр аракы эчүдән чирләгән вакытларны хисаплый башласаң, ул ничә үлемнән калды икән?* Ф.Садриев. *Күп төймәле чутын алып, Инде хисаплый башлый: Саннарга саннарны куша, Ансын да тиздән ташлый.* Ф.Тарханова

**Хисаплый китү** Башка эш яки сүз уңаеннан гына хисаплау. *Хисаплый китсәң, ул йөз меңлек гаскәр юллый ала иде.* Р.Батулла

**ХИСАПЛАШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **хисаплау**. *Үзе генә санамады, хезмәттәшләре дә хисаплашты*

2) *сөйл.* Кем белән булса да исәп-хисап ясау; исәп-хисап эшләрен өзү, санашу: кирәк кадәр түләү. – *Ярый алайса, соңыннан хисаплашырбыз, ихтыярың, – дип, кесәсеннән тартып чыгарган кулын Гыйлемханга сузды җитәкче.* Р.Мөхәммәдиев. *Шунда ук хисаплашырга кесәңдә сәмәнең булмаса, я очкычыңны бикләп куялар, я чалбарыңны салдырып калдыралар.* Р.Ибраһимов

3) *күч.* Билгеле хәлләрне, шартларны, тәртипләрне игътибарга, исәпкә алу; исәпләшү. – *Бу хәл белән дә хисаплашмый чарабыз юк, кадерлеләрем, – диде.* А.Хәсәнов. *Алар белән хисаплашмау, йомшак кына әйткәндә, акылсызлык галәмәте түгел.* Р.Батулла

4) *күч.* Үч алу. *Вакыты җиткәч хисаплашу*

**Хисаплаша башлау** Хисаплашырга тотыну; билгеле бер моменттан соң хисаплашу. *Ул әдәп өчен генә Баһадурның тәкъдимен кире кагып маташса да: «Әйе, минем белән хисаплаша башладыгызмы? Шулай ул!» – дип уйлап алды.* Ф.Абдуллин

**Хисаплашып алу** Тиз арада хисаплашу. *Хисаплашып алганнан соң берберсенә серле караш ташладылар да сөйләшми генә эшләрен дәвам иттеләр.* М.Вәлиев

**Хисаплашып бару** Даими, системалы хисаплашу. *Кирәкми дә, әгәр кеше, бер игелек кылган саен, мин болай иттем, мин тегене эшләдем дип хисаплашып барса, кылган гамәлләренең бер савабы да калмаячак.* З.Мурсиев

**Хисаплашып бетерү** Хисаплашуны төгәлләү. *Быел тракторларны 50 процент бәядән җибәрмәкче булабыз, киләсе елда программа яңадан торгызылгач, республика завод белән хисаплашып бетерәчәк.* Ватаным Татарстан

**Хисаплашып йөрү** Әле, хәзерге вакытта хисаплашу; озак вакыт хисаплашу. *Элек эшләгән оешма белән хисаплашып йөреп күпме вакытың әрәм булды ---.* Идел

**Хисаплашып кую** Алдан хисаплау. – *Шул вакытта ук хисаплашып куясы калган, – дип көрсенде егет.* И.Нуруллин

**Хисаплашып тору** Әле, хәзер хисаплашу; даими яки әледән-әле хисаплашу. *Бай яктан шактый акча белән кайткан иде ул, бәясе-ние белән хисаплашып тормыйча, чувашлардан бер еллык печкән үгез дә алып суйды, күрше базардан бер-ике капчык алабута оны белән ярты капчык арыш оны, тагын күпмедер тары да алып кайтып бирде.* Ә.Еники. *«Без бит инде бертуган кук, туганнар хисаплашып торамыни», – дип, мин дә каршы яздым, ләкин: «Кал, китмә, бездә тор», – дигән сүзләрне өстәмәдем.* Л.Ихсанова

**ХИСАПЛЫ** *с.* **1.** 1) Хисапка, исәпкә алынган, төгәл исәбе булган, саналган. *Хисаплы мал җуелмас.* Әйтем

2) Акча һ.б. нәрсәләр белән исәпләп, уйлап эш итә торган; экономияле. *Хисаплы кеше*

3) *күч.* Чикле, санаулы, исәпле; аз, кадерле. *Өй эчендә сөйләшеп утырырга бер дә таныш кеше булмаганга, мавыгып утырырга эш тә булмаганга, үткәргән вакытлары бик хисаплы, минутлары берлән билгеле иде.* Г.Исхакый. *Хисаплы ул шикәрне мин әтиәнидән урлап ала идем.* Р.Батулла

**2.** *и. мәгъ.* Исәп-хисап ярата торган, акчаның, малның кадерен белә, исәпләп тота торган, экономияле кеше. *Хисаплының малы исәпле.* Әйтем

**ХИСАПСЫЗ** *с.* **1.** Бик күп, иксезчиксез, исәпсез, бихисап, исәбе юк. *Зур шәһәр хисапсыз утлары белән җемелди, мең төрле серне, катлаулы йөрәкләр тибешен чагылдыргандай булып күренә иде.* М.Маликова. *Кендек әби, Гөлҗәүһәрнең тәнендәге хисапсыз кара янган урыннарны күреп: «Һай, балакаем, ни хәлләр түзәргә кирәк. Күпме бәби кабул итеп, мондый җәбер кичергән хатын-кызны беренче күрәм», – дип аптырап калган.* Г.Галиева

**2.** *рәв. мәгъ.* Гадәттән тыш, бик, искиткеч күп. *Сугыш беткәннән соң аның күкрәгендә значоклар, медальләр хисапсыз күбәйде.* Р.Батулла. *Ул очракта һәр ике яктан югалтулар хисапсыз булачак.* Р.Мөхәммәдиев

**ХИСАПЧЫ** *и.* 1) Җитештерү тармагына караган предприятиедә башкарылган эш күләмен, эшче санын теркәү һ.б.ш. гади хисаплау эшләрен алып баручы хезмәткәр. *Әти, шахтага төшеп, күмер чокый, әнием күмер озату станциясендә хисапчы булып урнаша.* З.Хәким. *Унынчыны бетергәч тә, сәләтен күреп, фермага хисапчы иттеләр (мәктәпкә күчкәнче, Яңыл шул эштә эшләде), шуннан ул тиз үрләде.* Р.Камал

2) Бухгалтер. *Дөрес, Мөнирҗан атлар карарга иртәрәк кузгала, аны озатып күп тә үтми, хисапчы да колхоз идарәсенә тырт-тырт атлап китеп бара.* Н.Әхмәдиев. *Сабакташларым, чират белән, хыял иленең капкасын шакый: әнә берсе, юрист, ди, икенчесе – хисапчы, өченчесе...* Н.Гыйматдинова

**ХИСАПЧЫЛЫК** *и.* 1) Исәп-хисап алып бару эше; бухгалтерия. *Минем урынга калган бер яшь кенә кыз хисапчылык эшен юньләп алып бара алмагач, кырык икенче елда аның урынына Сәкинәне куйганнар, һәм ул әле дә шул эшендә эшли иде.* В.Нуруллин. *Хисапчылыкка махсус укыган кеше түгел бит Сәетгәрәй, әллә исәп-хисапны бутап бетергән, әллә инде...* Р.Төхвәтуллин

2) Исәп-хисап эшләренә өйрәтә торган фән, предмет; бухгалтерия. *Моннан тыш, хисапчылык, техник исәп-хисап һәм смета фәннәре укытылуын искә алсак, төзелеш-техник училищесында хәзерге университетның күпчелек белгечләренә, аның эшчәнлегенең күп юнәлешләренә нигез салынганлыгын күрәбез.* Фән һәм тел

3) Хисапчы булу; хисапчы һөнәре. *Ярар алайса, син дигәнчә булсын: хисапчылык ошамый икән, эшкә фермага барырсың.* Н.Әхмәдиев. *Либераль бай Хөсәенов конторында хисапчылык итә.* К.Кәримов

**ХИСАР** *и. гар. иск.* Ныгытылган корылма, ныгытма. *Хисар алдында бер олы капка күрде.* К.Насыйри. *Бер үк вакытта кырык мең яугир сыярлык хисар да, гарәп әмирләренең истирахәт чигеп яшәгән оҗмах бакчалы, фонтаннар белән бизәлгән тәхет сарае да булган ул Әлһәмра.* М.Юныс

**ХИ́С ИТҮ** *ф.* 1) Күңел белән сизү, нинди дә булса хис тою, тойгы кичерү. *Рөстәм саклык өчен дөресен әйтмәде һәм шуңа күрә үзен уңайсыз хис итте.* Г.Кутуй. *Мин бүген тора торыштан рух төшенкелеге, эч пошу хис иттем.* Г.Рәхим

2) Күз алдына китерү; үзен билгеле бер җирдә, вакытта дип уйлау һәм шундагыча тою, шул җирдә, урында яки

вакыттагы кебек рухи халәттә булу. *Ә киләчәкне күрү, шуны күрәм дип хис итү иң авыр минутларны да җиңел һәм күркәм итә.* Г.Кутуй. *Зәйтүнә үзен нәкъ Индиядә кебек хис итәргә тиеш.* Г.Каюмов // Үзен шул җирдәге, урындагы кебек тоту. *Мусага да: «Үзеңне биредә өеңдәге кебек хис ит», – диделәр.* Г.Әпсәләмов

3) Уйлау, күз алдына китерү; үзен ниндидер яки кемдер дип исәпләү; үзен шулай тою. *Ләкин сез үзегезне әсир итеп түгел, ә минем коллегам дип хис итегез.* В.Нуруллин. *Уналты тиенне учына йомарлап кибеткә барганда, аннан ипи күтәреп кайтканда үзен иң бай кеше итеп хис иткән малай өчен бу – башка сыймаслык зур акча иде.* А.Әхмәтгалиева

4) Төрле хисләр тою, хис-кичерешләрне аңлау, хисләр дөньясында яшәү. *Матур әдәбият, сәнгатьнең бер төре буларак, хис итәргә этәрә, рухи баета, укучысының рухын тәрбияли.* А.Әхмәдуллин

5) Сәламәтлеге, физик һәм рухи халәтенә бәйле рәвештә үзен билгеле бер дәрәҗәдә, хәлдә сизү, тою. *Шушы егылудан соң ул үзен байтак вакыт бик начар хис итә.* А.Хәсәнов. *Зур кайгы булып узганнан соң гына кайберәүләр үзләрен начар хис итүләрен, кайберләренең йөрәкләре кысуларын, кайберләренең кинәт кенә авырсынып, күңелсезләнеп китүләрен искә төшерделәр.* А.Нәҗми

**ХИСЛӘНҮ** *ф.* Хискә бирелү, хискә чуму. – *Рәхмәт, – дип сузды хисләнгән Рамилә.* М.Маликова. *Айның тулган чакларында ул элегрәк тә хисләнә, иләсләнә, йоклый алмый изалана иде.* Р.Мулланурова

**Хисләнә бару** Акрынлап, торган саен хисләнү. *Егет, аның саен хисләнә барып, сүзен дәвам итте: – Исеңдә тот: бүген дә, иртәгә дә, берсекөнгә дә, син килгәнче, беркая китми көтеп утырачакмын.* И.Диндаров

**Хисләнә башлау** Хисләнү билгеләре сизелү, күренү. *Кулыңа тотуга хисләнә башламагач, геройлары белән кайгырмагач-сөенмәгәч, күңелеңә хуш җырларен кайта-кайта укымагач, шушы да булдымы китап уку!* Р.Фәйзуллин. *Болай да артык хисләнә башлаган йөрәк әллә нишли, күңел түрендәге истәлекләрне яңартырга тотынасың.* Кызыл таң

**Хисләнә төшү** Бераз хисләнү; тагын да хисләнү. *Бу җырны тыңлап тагын да хисләнә төштем, күзләремә яшь килде, чынлап та, бик сагынганмын икән туган ягымны ---.* Мәйдан

**Хисләнеп алу** Берара, бераз гына хисләнү. *Ачык тәрәзәдән башымны тыгып, шулар белән хисләнеп алдым да, юрганымны бөркәнеп, йокы ләззәтенә чумдым.* Ч.Шакирова

**Хисләнеп бетү** Тәмам, бик нык хисләнү; бик нык хислегә әйләнү. *Югыйсә кайбер авторлар, тәмам хисләнеп бетеп, балачак шуклыкларын – күрше бакчасына кыяр чәлдерергә керү кебек вак-төяк хатирәчекләрен дә укучыга сөйләүдән тайчанмыйлар.* Ф.Бәширов

**Хисләнеп йөрү** Озак вакыт хисләнгән халәттә булу. *Менә шундый уйлар белән хисләнеп йөргәндә, бер атна да үтмәгәндер, җирдән көткәнне Ходай Тәгалә миңа күктән бирде.* Р.Зарипов. *Алай хисләнеп йөрергә вакыт юк безнең.* Ватаным Татарстан

**Хисләнеп китү** Кинәттән, көтмәгәндә хисләнү. *Хисләнеп китеп, «өйләренә барыйммы әллә» дип уйлаган идем, акылым «барма, йөрмә» дип тыйды.* А.Гыйләҗев. – *Мең рәхмәт, башыңа андый фикер килгәне өчен! – диде Фәләх һәм, хисләнеп китеп, аны үбеп тә алмакчы иде, ләкин Гасимә бармагын ирен турына куеп: – Т-с-с-с, ярамый, иптәш Мөхәммәтов, әнә безне күреп торалар анда! – дип читкә тайпылды.* В.Нуруллин

**Хисләнеп тору** Хәзер, әле хисләнү; әледән-әле, һәрвакыт хисләнү. *Дөресрәге, анда кереп, балконнан дөньяны күзәтеп, хисләнеп торырга вакыт калмый иде.* М.Садыйков. *Егет аны иелеп ала, яңагына куеп, хисләнеп тора, аннары үз тәненә куеп, таманлыгын карый...* Г.Гыйльманов

**Хисләнеп утыру** *сөйл. к.* **хисләнеп тору**. *Безгә дә бәйрәмнән соң озак хисләнеп утырырга туры килмәде.* Безнең гәҗит

**ХИСЛЕ** *с.* **1.** 1) Хискә бай, хисчән, хисләргә бирелүчән, эмоциональ (кеше тур.). *Менә сез – импульсивный, хисле, тәэссоратларга сизгер җан.* А.Гыйләҗев. *Шагыйрь иде, нечкә күңелле һәм хисле кеше иде, мәрхүм...* З.Мифтахов

2) Хис, тойгы белдерә торган; хис тулы. *Үзләре хисле, дәртле шаян җыр җырлыйлар, ә күз карашларында – сагыш, йөзләрендә, кемгәдер үпкәләгәндәй, караңгылык чалына...* В.Нуруллин. *Синең хисле, якты хатыңны алгач, шигырь яздым бит әле.* З.Мәхмүди

3) *күч.* Кемдәдер хис уяткан, кем өчендер хис чыганагы булган; хискә бай; серле, үзенчәлекле. *Хисле май ае иде ул...* Р.Харис. *Кулы тиде кебек шунда хисле тәнемә...* Ф.Яхин

**2.** *рәв. мәгъ.* Хис белән; тәэсирле итеп, хис-кичерешләргә бай итеп. *Барысын, якташ, хисле язгансың; Ләкин өмет өзмә; Өзәрбез дә дошман боҗрасын, Чыгарбыз бер без дә.* Г.Хуҗиев. *Иске танышлар бик хисле итеп күрешәләр.* Р.Батулла

**ХИСЛЕЛЕК** *и.* 1) Эмоциональлек, хискә бирелүчәнлек. *Ул кул-битләрен чылатты да, күптәннән көткән морадына ирешкән хислелек белән, тагы да: – Гаҗәп! – диде.* И.Юзеев. *Тик шулай булса да, хислелеге, уйчанлыгы, хәтта сагышы белән сөйкемле, мөлаем үзе...* М.Маликова

2) Тәэсирлелек, хис уяту үзлеге. *Алар хикәяләүгә хислелек, лиризм, моңлы музыкальлек аһәңнәре бөркиләр.* Ф.Хатыйпов. *Мәгънәне тирәнәйтү, образлылыкны көчәйтү, хислелекне арттыру максаты белән, ул борынгы төрки теленнән килгән формаларны мул куллана.* Кызыл таң

3) Хис белән сугарылган булу, бай хисләр чагылдыру. *Н.Фәттах, Ә.Еники кебек әдипләребез аның иҗатының хислелеген, тәэсирлелеген таный һәм нәкъ шуны әдибәнең зур үзенчәлегe дип саный.* Р.Рахман

**ХИССА** *и. гар. иск.* 1) Өлеш, кемгә дә булса тиешле күләм; пай. *Мөәззин боларның яңа чапаннарын күргәч ук, чапаннар янына килеп: «Минем хиссам кая? Мин – мәхәллә мөәззине, мине ник өлештән калдырасыз?» – дип орышырга тотына.* Г.Исхакый. *Мөселман хиссасына төшәчәк микъдар мөселманнарның үзләренә бирелер.* Фәнни Татарстан

2) Нәтиҗә; кыйссадан алынырга тиешле гыйбрәт, мораль. *Башым – тубал, чыгарыйм соң Бу кыйссадан нинди хисса?!* Р.Идиятуллин. *Мәҗнүн мәхәббәте турында сөйләгән «кыйссадан хисса»* чыгарыла. Л.Мөхәммәтҗанова

**ХИССЕЗ** *с.* **1.** 1) Хисе булмаган, бернәрсәгә дә исе китми торган, хис-кичерешләре булмаган. *Хиссез ул, салкын ул, җансыз ул!* Н.Гыйматдинова. *Баланың инде таныргылыгы калмаган, ул елый да, көлә дә белми торган хиссез һәм акылсыз бер мәхлукка әверелгән, ул инде яшәми, ә сантыйлар сабырлыгы белән әҗәлен көтә иде.* М.Кәбиров

2) Берни дә хис тә чагылдырмаган, җансыз; битараф. *Ниндидер уйсыз, хиссез бер хәлдә утырды ул.* Г.Әпсәләмов. *Җавабын да хиссез, коры тавыш белән*

*тезеп салды: – Тумаган колынның билен сындырмыйлар.* В.Имамов. *Чыгыбрак торган зур бәбәкле, хиссез, салкын булып тоелган соры күзләре Таһирны үтәли тишәрдәй итеп баштанаяк сөзеп чыкты.* Д.Булатова

3) *күч.* Бернинди хис уятмый торган; кызыксыз, күңелсез, салкын, ят. *Өнебездә булсынмы, төшебездәме – аның назы һәм җылысыннан башка хиссез дөньяда итеп тояр идек үзебезне.* А.Нәҗми. *Хиссез өйне ялкын чорнап алып, Хыялларын ваклап яндыра, Ә җил карап тора. Ялкын, күккә кабып, Төнне караңгысыз калдыра.* Б.Ибраһим

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Хискә бирелмичә, дулкынланмыйча, битараф рәвештә. *Илле сигез елның күпме көннәрен аңсыз, хиссез, мәхәббәтсез, күңеле нурсыз килеш, җаны булганга гына кыймылдап, шуышып, газапланып үткәрде икән ул!..* А.Гыйләҗев. *Туган туфрак, Ватан язмышы, аның данлы-шанлы һәм фаҗигале узганы турында хиссез язып буламыни!* Р.Батулла

2) Бернинди хис чагылдырмыйча. *Хат аның кулында әкрен селкенә, әмма тавышын сынып китүдән саклагандай, сүзләрне юри хиссез итеп, өзеп-өзеп кенә укый: «Абыем, син мине күргәч, – дип яза кыз, балаларча беркатлылык белән, – танымассың да инде ---».* Ә.Еники

**ХИССЕЗЛӘНДЕРҮ** *ф.* Хиссез итү, хиссезгә әйләндерү, күңелен тупасландыру, битараф итү; хиссезгә, битарафка, шәфкатьсезгә әйләндерү. *Кешене хиссезләндереп, уй-гамен йокы казармалары арасында адаштырган, күндәм бер мәхлукка әверелдергән сөмсез архитектура үрнәкләре бөтен республикаларга җәелде.* М.Галиев. *Ә бит технологик бәйләнешләр кешеләрне хиссезләндерә, уйлау сәләтебезне саектыра.* Шәһри Казан

**Хиссезләндерә башлау** Хиссезләндерергә керешү. *Карагыз әле сез кешеләргә, --- заман безне чынлап та хиссезләндерә башлады.* Сөембикә

**Хиссезләндереп бетерү** Тәмам хиссезләндерү. *Бу гаджетлар балаларны хиссезләндереп бетермәс дип кем әйтә ала?!* Л.Вәлиева

**ХИССЕЗЛӘНҮ** *ф.* 1) Бернәрсәгә дә исе китмичә, йөрәгенә, күңеленә тирән алмыйча гына, битараф карый торган булу. *Күңле калган көл-күмергә әйләнеп, хиссезләнеп ---.* Г.Тукай

2) *күч.* Рәхимсезләнү, миһербансызга, шәфкатьсезгә әйләнү, кырыслану, усаллану. *Җавап заманның хиссезләнүендә, моңсызлануында булса кирәк.* Ватаным Татарстан

**Хиссезләнә бару** Торган саен күбрәк хиссезләнү. *Һәм моңа гаҗәпләнәсе дә юк, чөнки барыбыз да хиссезләнә барабыз.* Кызыл таң

**Хиссезләнә башлау** Хиссезләнү билгеләре сизелү. *Хиссезләнә башлаган күңелләрне уятып кара син!* Мәйдан

**Хиссезләнә төшү** Бераз хиссезләнү, тагын да күбрәк хиссезләнү. *Әйе, авыр сынаулар аны үзгәрткән, ул инде элеккеге көләч егет түгел, --- чәчләре агарган, тагын да боеккан, хиссезләнә төшкән.* М.Вәлиев

**Хиссезләнеп бетү** Тәмам хиссезләнү. *Хиссезләнеп беткән хисапчылар санамаган сине кешегә.* З.Мансуров

**Хиссезләнеп калу** Билгеле бер вакыттан соң яки билгеле сәбәпләр аркасында хиссезләнү. *Җан шифасы була күрешү – Хиссезләнеп калса күңелең.* Ф.Исмәгыйлева

**Хиссезләнеп йөрү** Озак вакыт дәвамында хиссезләнү. *Хиссезләнеп йөргән чакларымда Син очрадың кабат юлымда.* Э.Сафина

**Хиссезләнеп тору** Әле, хәзер хиссезләнү, соңгы вакытта хиссезләнү. *Хиссезләнеп торырга вакыт юк, тимерне кызуында сугарга кирәк иде ---.* Идел

**ХИССЕЗЛЕК** *и.* Хиссез булу сыйфаты; бернинди дә хис булмау хәле; битарафлык. *Җан ул шундый – төссезлектән башлый, хиссезлеккә таба күчenә...* Р.Харис. *Сугыш афәтләрендә, мөсафирлык язмышында, сөргеннәрдә күңел бөтенлеген саклап калырга ярдәм иткән ул, бүген дә хиссезлектән, туң йөрәк булудан коткара.* Кызыл таң

**ХИССИ** *с. гар.* 1) Хисләр өлкәсе белән бәйле, эмоциональ. *Халык җыры – бөек шигърият әсәре ул.* Р.Яхин. *Абдуллиннарның татар җырларын хисси яктан бай һәм тәэсирле итеп, моңны тирән тоеп җырлауларына соклана.* Т.Әйди. *«Анда иксез-чиксез хисси байлык, моң, хикмәтле, сурәтле фикерләр, тел бизәкләре тулып ята...» – ди ул үзенең бер язмасында.* Р.Фәйзуллин

2) Хискә бай, хис тулы. *Белмим, хисси романнар бик күп укыганга, белмим, җитдирәк китаплар укыганга, белмим, башымнан төрле эшләр кичеп, балалыктан кешелеккә күчкәнгә, мәхәббәт, гыйшык кеби нәрсәләргә бик аз ышана идем.* Г.Исхакый. *Әти, пнимаете ли, тормыштан бер адымга артка калып бара, яраткан улының хисси дөньясын, тәвәккәллеген аңларга теләми.* Т.Галиуллин

3) Лирик. *Хәзергә бу мәсьәләне калдырып торып, хисси җырларыбызга күчмәкче булам.* Г.Рәхим. *Бер рәхәтләнеп Илһамны тыңларга дип җыелган халык шагыйрь Моррисның хисси шигырьләрен тыңлый-тыңлый тинтерәде.* Х.Ибраһим

4) *күч.* Хисле, серле, үзенчәлекле; матур хис-тойгылар уята торган. *Туган тел үсәр Гөлдә ачылып. Гөлдә – таң нуры – Хисси алсулык...* Ф.Гыйззәтуллина. *Ак карлар эз сала җиргә, Буран-нары – хисси. Кыш, кулына каурый алып, Тәрәзәне бизи.* Р.Сәлах

**ХИССИЯТ** *и. гар.* Хис-тойгылар; хисләр. *Кан тамырларына илһам, көч булып йөгергән калеб – иман, вөҗдан, көч, акыл, хиссият – сабый зиһендә кешелек хакына изгелек кылу теләген тудыра...* А.Хәлим. *Син – нечкә күңелле, хиссият кешесе.* З.Хәким

**ХИССИЯТЛЕ** *с.* Хискә бирелүчән, хисле, хискә бай; нечкә тоемлый торган. *Күпчелек шагыйрьләребез – иң хиссиятле шәхесләр – шуңа күрә дә тиз яндылар, озак яши алмадылар.* М.Шабаев. *Ачык, мөлаем, шат күңелле холкы белән ул – әдәби җәмәгатьчелектә җылы, көр хиссиятле, оптимистик мохит тудыручы затлардан.* Н.Хисамов

**ХИСЧӘН** *с.* Хискә бирелүчән, сизгер, хисле. *Исеме бер сулыш белән, йөрәк түреннән чыккан наз белән әйтелә торган, якты карашлы, ачык холыклы, моңлы һәм хисчән авыл кызы явызлыкка каршы беренчеләрдән булып күтәрелгән икән һәм һәлакәтен дә башын югары тотып каршы алган икән – бу аның табигатенә шулкадәр туры килә!* М.Маликова. *Элекке оялчан, хисчән, елмаеп кына тора торган мөлаем кыз урынында бөтенләй бүтән Гөлсинә...* Р.Мулланурова

**ХИТ** *и. ингл.* **1.** 1) Билгеле бер вакыт аралыгында аеруча популяр булган җыр. *Киләчәктә әле хитлар булырдай яңа җырлар язу хыяллары да бар Лилиянең.* А.Галимов. *Хәния Фәрхи башкарган «Сагынам сине, Питрәч», «Үпкәләсәң, әйдә, үпкәлә», «Кайтам әле Әлдермешкә», «Утыр әле, әни, яннарыма» җырлары мәңгелек хит булып халык күңелендә урын алды инде.* Акчарлак

2) Аеруча зур уңыш казанган, халык тарафыннан яратып кабул ителгән сәнгать әсәре (фильм, китап, спектакль һ.б.ш. тур.). *Күпләр фикеренчә, үткән*

*елның хиты булырлык, ягъни иң күп сатып алынган һәм иң күп укылган китапның берсе, һичшиксез, «Зөләйха күзләрен ача» китабы.* Л.Галиева

**2.** *с. мәгъ.* Бик популяр, танылган, күпләргә таныш. *Мәсәлән, актёр, сәхнәдә төп рольне уйнап, яисә җырчы, хит җыр башкарып, халык арасында танылу яулый икән – аның фикере буенча «ул – иң шәбе».* Кызыл таң

**ХИТАП** *и. гар.* Кемгәдер юнәлдерелгән, адресланган сүз яки язу, мөрәҗәгать. *Алланың бу хитабы гүяки ике адымлык җирдә генә суккан яшен шикелле яңгырап китте.* Г.Тукай. *Дөрес, күп кенә газеталар, мәсәлән, «Көрәш» (Уфа), Исмәгыйль Рәмиев күзәтүенчә, «мөмкин кадәр әзер материал, декрет, карар, хитап, игъланнар белән тулып чыга иде».* И.Низамов

**ХИТА́П ИТҮ** *ф.* Сүзне юнәлдерү, мөрәҗәгать итү, эндәшү. *Кызның атасы сарай халкына хитап итеп: – Минем дәртемә бер чара итмәк кирәксез, вә илля күп зарар күрерсез, – дип, гайрәт белән үзен һәлак итмәк эстәде.* К.Насыйри. *Шунысы кызык: гүя ул үзе түгел, үтергән өчен хөкем итүчеләр гаепле, шәһәрдән чыккач, Аллага хитап итеп, болай ди: «И Ходаем, мине бу миһербан-шәфкатьсез халыктан коткара күр».* Г.Гобәй

**ХИТА́П КЫЛУ** *ф. иск. к.* **хитап итү.** *Әбелхарис, хәлвәфрүшкә хитап кыйлып: – И егет, Мисырга кайтырга морадың бармы? – диде.* К.Насыйри

**ХИТАПНАМӘ** *и. гар.-фар.* Язма мөрәҗәгать, язма хитап. *Кәгазь юклыктан, күрәсең, хәзер хитапнамәләр, өндәмәләр, газеталар – барысы да тотсаң ертылырга, уалырга торган шундый сары кәгазьгә басылалар.* А.Шамов. *Ул әле Сталинга хитапнамә язачак.* С.Поварисов

**ХИТИН** *с. гр. махс.* Кайбер бөҗәкләрнең, үрмәкүчләрнең, кыслаларның һ.б. каты кабырчыклы кабыгын хасил итә торган органик матдә. *Краб, кысла кебек буынтыгаяклыларда хитин минераль тозлар сеңүдән катылана, ныгый һәм панцирьга әйләнә.* Биология. *Табиблар аңлатуынча, гөмбә хитин һәм целлюлозадан тора.* Мәйдан

**ХИТ-ПАРАД** *и. ингл.* Тыңлаучылар, укучылар тарафыннан сайланган иң әйбәт башкаручылар; аеруча популярлык яулаган җырлар, китаплар һ.б.ш. исемлеге. *Шулай итеп, хит-парадыбызның җиденче баскычында Илһам Шакиров булды.* А.Хәмзин. *«Татарстан – Яңа Гасыр» телеканалының «Кәеф ничек?» хит-парадында Салават Фәтхетдинов башкарган «Юлчы» дигән җырны атна саен тыңласам да, соңыннан һәрвакыт ниндидер тирән хисләр дөньясына чумам.* Т.Нәҗмиев

**ХЛОР** *и. гр. хим.* Яшькелт сары төстәге химик элемент; дезинфекция чаралары, химик корал җитештерү һ.б. өчен кулланыла торган тын буудыргыч газ. *Һәр көнне шул биш катлы бинаның ишекләрен ачып керә Рәшит, чиста итеп юылган, хлор, дару исе аңкып торган озын коридорлардан үтә.* Р.Габделхакова. *Шунда ук хлор катыш дару исе борынын ярып керде, куллары үзен уратып алган ниндидер чыбыклар арасында буталды.* Х.Ширмән

**ХЛОРЕ́ЛЛА** *и. биол.* Аксымнарга һәм майларга бай беркүзәнәкле яшел суүсем. *Кайбер суүсемнәр (хлорелла) елга, буа һәм күлләрнең биологик чистартучылары буларак файдаланылырга мөмкин.* Биология. *Белгечләр фикеренчә, мондый яшел төсне суга хлорелла – микроскопик суүсем бирергә мөмкин икән.* Безнең гәҗит

**ХЛО́РКА** *и. рус сөйл.* Порошок яки эремә хәлендәге хлорлы известь. *Әнә, син әйткәнчә, бәдрәфтәге хлорка белән чистартып авызын яндырган бит.* И.Сиражи. *Җитмәсә, ниндидер профессор килергә тиеш икән: бар дөньяны хлорка исенә тутырып, юдылар, тазарттылар.* Д.Булатова

**ХЛОРЛАНУ** *ф. төш. юн. к.* **хлорлау**. --- *кунакханә тәртипләренә төкереп кенә карап, хлорлана торган бассейнда су коенып (безгә хлор – ни-пачум!), шәп итеп ял иткәннәр болар.* Сөембикә. *Ул чакта кош итен санитар эшкәрткәндә хлорланган су кулланылганы ачыкланды.* Өмет

**ХЛОРЛА́У** *ф. махс.* 1) Органик яки органик булмаган матдәләрнең молекулаларына хлор кертү. *Нитрометанны хлорлаган вакытта нинди матдә барлыкка килә?* Органик химия

2) Хлор ярдәмендә зарарсызландыру. *Моннан тыш, суны хлорлаганда, анда 40 төр нык зыянлы матдә барлыкка килә, шул исәптән хлороформ, дихлорметан, дихлорэтан.* Кызыл таң. *Депутат комиссиясе утырышында «Санэпиднадзор» вәкиле, безнең Түбән Кама шартларында эчәк инфекциясе таралмасын өчен, эчәр суны хлорлаудан башка чара юклыгы һәм аның альтернативасы булмавы хакында белдерде.* Туган як

3) Хлорлы матдәләр кулланып дезинфекция ясау. *Профилактик-дезинфекция бүлеге тарафыннан ел саен, халыкны геморрагик бизгәктән саклау өчен, 760600 кв. метрдан артык мәйдан эшкәртелә, 140 тан артык йогышлы авыру чыганакларын эшкәртү үткәрелә, 106 су башнясы хлорлана ---.* Хезмәт даны

**Хлорлап кую** Алдан ук хлорлау. *Суны хлорлап куйган иде*

**Хлорлап тору** Даими рәвештә хлорлау, гел хлорлау. *Бассейнны вакытында хлорлап торырга кирәк*

**Хлорлый башлау** Хлорларга тотыну. *Шуннан соң, төрле чирләр таралмасын өчен, эчәр суны хлорлый башлыйлар.* Кызыл таң

**Хлорлый төшү** Элеккегә караганда күбрәк хлорлау; тагын бераз хлорлау. *Идәнне көн саен юа торган булып китте, суын хлорлый төште ---.* Идел

**ХЛОРЛЫ** *с.* Хлор кушылган, составында хлор булган. --- *вагоннарны, чатырларны, кешеләрнең урын-җирләрен, кухняны, ашау-эчү, юыну-йөрү урыннарын – бөтен җирне хлорлы известь белән дезинфекцияләп чыктылар.* Н.Фәттах. *Нитрат эремәсенә аш тозы салсаң, хлорлы көмеш барлыкка килә дә төпкә утыра.* Т.Әйди

**ХЛОРОФИЛЛ** *и. гр. бот.* Үсемлекләрдә яктылык энергиясен химик энергиягә әйләндерә торган яшел пигмент. *Хлорофилл фотосинтез процессында органик матдәләр ясалуда бик әһәмиятле роль уйный.* Биология. *Суган кыякларындагы хлорофилл кан ясалуны яхшырта, шунлыктан аны азканлылыктан интеккәндә ашарга киңәш итәләр.* Мәдәни җомга

**ХЛОРОФОРМ** *и. гр. мед.* Төссез, тиз очып бетүчән, наркоз өчен кулланыла торган хлорлы сыекча. *Егетләр Чулпанны хлороформ белән йоклатканнар иде.* Х.Ширмән. *Ләкин хлор – үзе үк агулы, судагы башка матдәләргә кушылып, ул хлороформ, хлорфенол кебек канцероген матдәләргә әверелә.* Кызыл таң

**ХЛОРОФОС** *и. хим.* Корткыч бөҗәкләргә каршы көрәшү өчен кулланыла торган агулы препарат. *Корткыч бөҗәкләргә хлорофос даруы сиптергәндәй, агулы тәтеннәрен сиптереп китәләр.* Н.Хәсәнов. *Агачларны чишкәннәр, хлорофос сиптергәннәр, кишер чәчкәннәр, гладиолус утыртканнар һәм, яшел килеш йолкып алыр өчен, бераз суган төрткәннәр.* Ф.Яруллин

**ХЛОРПИКРИН** *и. гр. хим.* Төрле максатларда кулланыла торган зәһәр исле, төссез агулы сыекча. *Противогазларны махсус палаткада күздән яшь агыза торган хлорпикрин дигән агулы матдә белән сынап, эш киемнәре кигәннән соң, --- мәйдан уртасына бик зур ак материя җәелә.* Ә.Сафиуллин

**ХЛЯ́СТИК** *и. рус.* Пальто, шинель кебек киемнәрнең арткы өлешендә, бил турысын җыеп тору өчен, тегеп яки төймәгә эләктереп куела торган тар гына билбау кисәге. *Башында тушкырыла төшкән кара кепка, өстендә хлястигы салынып торган иске соры шинель, аягында үкчәләре шактый ашалган, ремонтта булган хәрби ботинка.* А.Шамов. *Шинельнең артында ике сәдәфкә эләктерелә торган хлястик дигән хикмәте бар.* М.Галиев

**ХОДА** *и. фар. к.* **Ходай**. *Әллә нинди газ сөремнәре белән агуланган, кортлы сулар эчеп әгъзаларын бозып бетергән солдатлар әти булу бәхетенә ирешкәч, мәрхәмәтле Хода кодрәте белән изге җаннарга әйләнәләр дип исәпли иде Хәлил...* А.Гыйләҗев. *Һәм, ниһаять, Хода аның догаларын ишеткән шикелле: Илүзә эчкече иреннән котыла ---.* З.Мурсиев

◊ **Хода бәндәсе** 1) Дин юлында йөрүче; динле, иманлы кеше. *Менә шул изге карт – татарларда Ак бабай дип йөртелә торган Хода бәндәсе – бөтен кешене каратып, Таһирны кочаклап алды.* Г.Гыйльманов; 2) Изге күңелле, ярдәмчел кеше. *Ифрат изге, ярдәмчел, Хода бәндәсе Мөнирә апа ут янар Яруллаauthor үзе белән интегүен сизә, аңлый, күпме тырышса да, иренә ярый алмый, чөнки ул барыбер Бердәнберенең яраткан чынаягын идәнгә төшереп ватачак, чүп чиләген вакытында бушатырга онытачак ---.* Т.Галиуллин; 3) Артык юаш, беркатлы, ихтыярсыз, карусыз кеше. *Анасы кушканны гына эшләргә гадәтләнгән чарасыз Хода бәндәсе үз көнен үзе күрә башлады: иң тәүдә тавыклары, аннан сарыклары яңа хуҗаларга таралды, арандагы бердәнбер ат – карт алаша да арбасы, чанасы, дирбиясе белән күрше авылга китеп барды.* Л.Зөлкарнәй; 4) *ирон.* Кеше, адәм баласы. *Хәтер түгел – хәмер кирәк Сиңа, Хода бәндәсе. Җир сукала, иген ик син, Я аркан иш... комлыкта...* Г.Морат. *Бердәнбер көнне бу Хода бәндәләренең язмыш сукмаклары бөтенләй башка якка борылып кереп китте.* Г.Гыйльманов; 5) Фамильяр мөрәҗәгать сүзе. *Ә сиңа сөйләүдән миңа ни файда, Хода бәндәсе?* А.Гыйләҗев. *Әй Хода бәндәсе, ансы да батмый икән, чөнки дә син булган җирдә ут-күз чыга, олан.* Н.Гыйматдинова. **Хода боерса** *к.* **Алла боерса**. *«Шүрәле» --- Хода боерса, алдагы бер нәшерләребездә укучыларга тәкъдим ителер.* Р.Гыйлемханов. **Ходага тапшыру** *к.* **Аллага тапшыру**. *Ходага тапшырып, төрле догалар укып, урманга кереп киттеләр.* Әкият. *Алып кер, алайса. Ходага тапшырыйк.* Н.Әхмәдиев. **Ходага шөкер** *к.* **Аллага шөкер**. *Килененең болай ачылуын күргәч, кайнана, Ходага шөкер, безгә иярләшә, безне тиң итә башлады, дип сөенде.* Ф.Яруллин. *– Ходага шөкер, киттеләр, – диде ул Таңчулпанга карап.* М.Хәбибуллин. **Хода кушса** *к.* **Алла боерса**. *– Ташы шартлап кыза торсын: Хода кушса, тиз күрешербез, – диелгән иде хатта.* Р.Батулла. **Хода кушып** Аллаһ ярдәме белән; Алла боерса. *Хода кушып, җәен Чураш агамның маллары ишәйсә, көзгә туй сыман нәрсә ясап та булыр иде.* Җ.Рәхимов. *Хода кушып, башта җимерергә насыйп булсын иде әле.* Д.Вәлиев. **Хода(ның) хикмәте** Искитәрлек гаҗәп хәл; могҗиза. *Менә бит, Ходаның хикмәте, ак торна да була икән!* Н.Әхмәдиев. *Менә, Ходаның хикмәте, сабыр итсәң, морадыңа ирешәсең икән бит.* З.Мурсиев

**ХОДАЙ** *и. фар. дини к.* **Алла**. *Мине ни өчен саклагандыр Ходай, берәүгә дә кирәгем юк иде югыйсә, яралансам да, исән калдым.* А.Әхмәтгалиева. *Җаным күккә менде, Ходай аны саклап тора. Хис йөрәккә керде, Акыл аны каплап тора.* А.Җамал

◊ **Ходай бәндәсе** *к.* **Хода бәндәсе**. *– Әй, Ходай бәндәсе, – диде ачынып Рәҗәпов.* Ф.Сафин. *– Исемең ничек соң синең, Ходай бәндәсе?* Р.Габделхакова. **Ходай бирсә** *к.* **Алла боерса**. *Мәңгегә, Ходай бирсә, мин аларның берсенә шәфкать күрсәтә торган кеше түгел.* А.Гыйләҗев. *Ходай бирсә, утыз ел чамасы гомерем калгандыр.* Ф.Бәллүр. **Ходай боерса** *к.* **Алла боерса**. *Ходай боерса, орлыгы Бохарда түгел, оныклар да озак көттермәс.* Н.Әхмәдиев. *Моннан ничә мең ел элек тә булганбыз, мең елдан соң да булырбыз, Ходай боерса.* Д.Булатова. **Ходайга тапшыру** *к.* **Аллага тапшыру**. *– Ярый, Ходайга тапшырдык, җаным... – дип, бүленә-бүленә сөйләнеп, артларыннан чыкты.* Ш.Камал. *Ходайга тапшырып риза булдым инде, хәерлегә булсын!* Р.Хәбибуллина. **Ходайга шөкер** *к.* **Аллага шөкер**. *Ходайга шөкер, безнең республикабыз Идел буе округында да, бөтен Россия күләмендә дә төшеп калганнардан түгел.* Р.Вәлиев. *Маһинур үзе дә, Ходайга шөкер, тугызынчы дистәгә җитә язды, әнисе Саимә карчык йөз яшен тутырып китте; ни авыр тормышта яшәгән, кайгылар күргән Өммегөлсем карчык та туксанны тутырды.* Р.Хәбибуллина. **Ходай каргаган** *к.* **Ходай орган**. *Ходай каргаган Нәзир: «Кызың качып китте, кайда ул? Түләгән калымымны кайтар!» – дип, бугазымнан алды, көтүдән биш куйны егып суйды...* Т.Әйди. **Ходай кодрәте** Аллаһы Тәгалә көче. *Кешеләрне бербере белән кавыштыру Ходай кодрәте икән.* С.Поварисов. *Ләкин кешене язмыш йөртә: Ходай кодрәте беләнме, кадерсез кызның аяклары кайтыр якка атлады да атлады...* З.Мурсиев. **Ходай кушса** *к.* **Алла боерса**. *Улыбыз булыр, Ходай кушса!* З.Зәйнуллин. *– Тагын шулай сөйләшеп утырырбыз әле, Ходай кушса, – дип, урынымнан торып бастым.* А.Мансуров. **Ходай күрсәтмәсен** *к.* **Ходай язмасын**. *Ул диспансерда йөрергә Ходай күрсәтмәсен.* Ф.Садриев. *Ач кешенең ачуын китерсәң, Ходай күрсәтмәсен, ул инде җенләнә-шашына белә.* С.Поварисов. **Ходай насыйп итсә** *к.* **Алла боерса**. *Ходай насыйп итсә, яңа эштә Бәхет ишекләрен ачармын.* Р.Маннапов. *Ходай насыйп итсә, Солтангәрәйнең бәхете булып, бәлкем, кодалашып та китәрбез, иншалла.* А.Гадел. **Ходайның (һәр) бирмеш (биргән) көне** Һәркөн, көн саен. *Шушы хәл Ходайның һәр бирмеш көнендә кабатлана башлады.* Э.Шәрифуллина. *Ходайның һәр бирмеш көне Хәтер көне болай да.* Г.Морат. **Ходай орган** Ачулану, сүгү сүзе. *Мин һәм бармакчы идем, ләкин теге, Ходай орган, бер кәвешне тәмам эштән чыгарган иде...* Ш.Камал. *Күтәреп карыйм – шактый авыр үзе, Ходай орган нәрсә!* Ә.Еники. **Ходай ризалыгы өчен** Чын күңелдән ярдәм итәсе килеп, үзенә файда түгел, савап булсын дип; түләүсез, бушка. *Мостафа җавап кайтарырга кирәклеген исенә төшереп: – Ходай ризалыгы өчен булсын инде, рәхмәт, Дәүли абзый, – дип кенә әйтә алды.* Ф.Сафин. *Агач-такта эшләрен, әнәгенәк, энең эшли. Ходай ризалыгы өчен анысы да.* Н.Гыйматдинова. **Ходай (хакы) өчен** Зинһарлап

үтенү сүзе. *Әхмәт, бер Ходай хакы өчен миңа чалма-чапан тап!* Ф.Әмирхан. *Юк, Җәмил, Ходай өчен, әйдә аерылышыйк.* Д.Салихов. **Ходай язмасын** Тәкъдиргә язылган булмасын, башка төшмәсен; алай була күрмәсен. – *Дустыгыз? – Ходай язмасын андый дусны, яшьтәш!* Р.Сибат. *Яшермим, Ризван Харисович, сезнең тирәләргә кабат аяк басарга Ходай язмасын, дип килдем.* Ә.Хәсәнов. **Ходай язса** *к.* **Алла боерса**. *Ходай язса, сезне аталы балалардан ким итмәскә тырышырмын.* Ә.Моталлапов. *Ярый, рәхмәт, татар кызы Анда кылды тәрбия. Ходай язса, сугышта да Табыла бит әүлия.* Ә.Хәсәнов

**ХОДА́Й ТӘГАЛӘ** *и.* Ходай, Аллаһы Тәгалә. *Ходай Тәгалә шаһит, рәхәт яшәмәдем.* М.Хәбибуллин. *Ходай Тәгалә сезнең аяк-кулларыгызны сызлаусыз итсен, гомерегез буена.* З.Зәйнуллин

**ХОДА́ТАЙ** *и. рус* 1) Нинди дә булса бер эш артыннан йөрүче, ниндидер эшне башкарып чыгу өчен билгеләнгән вәкил, ышанычлы кеше. *Ләкин ул авылның дөнья күргән, элек патшага ходатай булып йөргән, закон белгән кешеләре акларга ход бирмиләр.* Н.Исәнбәт. *Күрше авыллардан ходатай итеп шулай берничә орденлы ир-егетне һәм Гражданнар сугышында гаярьлек күрсәтеп дан казанган кешеләрне сайлыйлар.* Л.Хәмидуллин

2) Суд яки шундый башка урыннарда кемнең дә булса эшләрен алып баручы ышанычлы кеше. *Хәер, агайлар үзләре дә миннән ходатай булып йөрүемне сорамадылар.* Ә.Еники

**ХОЗРАСЧЁТ** *и. рус* Үз хуҗалыгын үзе алып бара, чыгымнарын үзе күтәрә торган хуҗалык, оешма. *Хозрасчётта без, әбекәй!* Ф.Имамов. *Колхоз акча кучерми, ә алар – хозрасчёттагы оешма.* М.Хәбибуллин

**ХОЗРАСЧЁТЛЫ** *с.* Хозрасчётка корылган, хуҗалык исәбенә нигезләнгән (предприятие, оешма, учреждение). *Мин быелгы хуҗалык елында Хәнәфи Габдуллин җитәкчелек иткән умартачылык тармагын, Зәйтүнә апаның тавык фермасын, шулай ук Габделхак Арслановның кырчылык бригадасын хозрасчётлы звенолар итеп оештырырга, алар белән шул хакта договорлар төзергә тәкъдим итәм.* С.Хафизов

**ХОЗУР** *и. гар.* **1.** 1) Рәхәт, ләззәт, күңеллелек; күңел тынычлыгы, канәгатьлек; күңелгә рәхәт булу. *Табигый булган бу шатлыклар, бу хозурлар өстенә авыл халкы үзләре тарафыннан да шатлык вә рәхәтләр кушып, бик күңелле бәйрәм – кыз озату, килен төшерү бәйрәме итәләр иде.* Г.Ибраһимов. *Без шулай, иртәгә буласы хозурлар турысында уйлый-уйлый, кичне үткәрдек.* Г.Рәхим

2) Күңелгә рәхәт, ләззәт бирә, күңелгә хуш килә торган нәрсә. – *Һәй, дөнья хозуры! – дип куанып кычкырып җибәрде Адаш абый.* М.Шабаев. *Февраль белән әгәр кыш мактанса, Көз хозуры – алтын сентябрь.* В.Галиев

3) Тартым яки килеш кушымчалары белән: билгеле моментта булынган урын; кемнеңдер каршысы, яны; кат. *Габделхәмит, һичшиксез, үлмәячәк, ә киресенчә, күкрәге тулы медальләр белән әнисе хозурына кайтып төшәчәк...* М.Мәһдиев. *Бакыйлыкка ана булып кучү – ул Аллаһы Тәгалә хозурына изге бурычыңны үтәп килү дигән сүз.* Г.Галиева

**2.** *с. мәгъ.* Ләззәт бирә, кәефне күтәрә торган; күңел ачардай матур, рәхәт. – *Бәхеткә генә була күрсен мондый хозур, мондый матур күренеш, – дип, үз нәүбәтендә, хыялый, күбәләктәй канатланган нәни кызына карап, нурлы айдай елмая.* Н.Каштанов. *Имеш, хозур җәй вакыты, искиткеч бер матур күлдә йөзеп йөрим.* Г.Якупова

**3.** *рәв. мәгъ.* Рәхәтләнеп, рәхәт итеп, рәхәт булып, тыныч күңел белән. *Ярый, сүз озынга китте, без бит әле өчәүләшеп читән тарантаста хозур гына авылыбызга кайтып барабыз.* Ә.Еники. *Кырда туктап, агачтан әле генә өзелгән җимешне ашау, әлбәттә, бик хозур булды.* М.Мәһдиев

**4.** *хәб. функ.* Шатлык, тулы канәгатьлек хисләре кичерү турында. *Аның һәрчак бизәлеп, төрләләнеп торуы хозур.* Г.Хөсәенов. *Яр буендагы балыкчыларга, су керүчеләргә карап тору да үзе бер хозур иде.* Н.Фәттах

◊ **Хозурга чыгу** Күңел ачу максаты белән кая да булса бару; ял итәргә чыгу. *Җәй көннәрендә мәдрәсә күршесендәге сәгатьче Камали абзыйның көймәсе берлә Чаган суыннан Рощага хозурга чыгып, шунда чәйләр эчеп, балык тотып күп көннәрен үткәрде.* Г.Кариев. *Яшьрәк вакытта ул бу тирәгә киек ауларга, хозурга чыгарга ярата иде.* З.Мәхмүди. **Хозур күрү** Ярату, соклану, яратып карау. *Җилпәзәләр тоткан сылу хурлар кебек, Зәйтүн гөлләр таңга калган хозур күреп.* Г.Афзал. *Хозур күрсәк бакча я кыр гөлләрен, Акыл һәм хис тудырган дөнья ямен, «Мин дә бар!» – дип, борнын суза Кигәвен.* Р.Гаташ

**ХОЗУ́Р ИТҮ** *ф. к.* **хозур кылу.** *Чираттагы археографик экспедициядән кайтып ялга чыккач, Идел буендагы Зелёный Бор дигән җирдә такта-фанердан әвәләнгән, гадәти эт оясыннан дүрт-биш мәртәбә генә зуррак булган бер казна алачыгында хозур итеп «корсак сыйпап» яткан көннәр.* М.Госманов

**ХОЗУ́Р КЫЛУ** *ф.* Рәхәт чигү, ләззәтләнү, матурлыкка соклану, ял итү, кәеф-сафа кору. *Ә хәзер тераска чыгып, бер хозур кылып утырыйк әле, сиңа әйтәсе важный сүз дә бар иде.* Ә.Еники. *Габделхәй белән болында хозур кылу ардырмый иде.* Г.Сабитов

**ХОЗУРЛАНУ** *ф.* Рәхәтлек кичерү, вакытны рәхәт уздыру; рәхәтләнү. *Таһир шул саф һаваны күкрәк тутырып сулаган, тирә-якка карап беренче тапкыр хозурланган.* Н.Акмал. *Әле яңа гына бөреләнеп, яшелләнеп килгән язгы алмагачларның матурлыгыннан хозурландым.* Х.Ибраһим

**Хозурлана башлау** Хозурланырга тотыну. *Эльвира шулкадәр үзенә ышанган иде ки, ул инде диссертациядәге цифрларны яңадан тикшергәндә картның көлкегә калачагын хәзердән үк сизенеп, эчтән явыз шатлык белән хозурлана башлады.* А.Расих. *Сәгать җиде-сигезләр тирәсендә Газәли мәхәлләсенең чәйханәсендә хозурлана башларбыз.* Т.Әйди

**Хозурлана тору** Әлегә, хәзергә хозурлану. *Әлеге сәяхәтебез турында алдагы көннәрдә тулырак язарбыз, ә бүгенгә фотолар белән хозурлана торыгыз.* Шәһри Казан

**Хозурланып алу** Кыска вакыт кына хозурлану. *Аш суынмасын дип кызукызу атлый, шул арада, тукталып, кәстрүлдән килгән хуш искә хозурланып ала.* Л.Сабирова. *Казансу елгасы буена килеп, шәһәр белән дә хозурланып алды Кыш бабабыз.* Туган як

**Хозурланып йөрү** Күптәннән яки гел, һәрвакыт хозурлану. *Әнә шулай үз уңышлары белән хозурланып йөргәндә, кинәт кенә авырып китте бит әле галим иптәш.* М.Галиев. *Мәдинә урамдагы гүзәллеккә, хуш искә хозурланып йөргәннән соң, ял итәргә исәпләп, өй каршындагы артлы эскәмиягә килеп утырды.* А.Әхмәтгалиева

**Хозурланып кую** Аз гына хозурлану. – *Каманы бик ямьле диләр, – дип, узалдына хозурланып куйды директор.* Р.Мөхәммәдиев

**Хозурланып тору** Сөйләү моментында хозурлану; озак вакыт хозурлану; гел, әледән-әле хозурлану. *Туктап ял итәргә, хозурланып торырга хәтта фонтаннары да бар.* Т.Әйди. *Отрядыбыз белән тауга менеп, диңгезгә хозурланып торганда, башка шундый уйлар килде.* В.Нуриев

**Хозурланып яту сөйл.** *к.* **хозурланып тору**. *Өрсәң, очып китәрлек, кош теле кадәр китап чыгарып, шуның күләгәсендә (билгеле, күләгә бик бәләкәй!) хозурланып ятмыйбызмы?* Р.Фәйзуллин. *Разил Вәлиев моңа кадәр ирешкән уңышларына канәгатьләнеп, хозурланып ятмый.* Шәһри Казан

**ХОЗУРЛЫ** *с.* Рәхәт, ләззәт бирә торган, күңелне ял иттерә торган. *Әмма бүгенге хозурлы манзара аның күңеленә мыскал да юаныч бирмәде, алай гына да түгел, бу минутта бөтен галәм ак кәфенгә төренеп ята сыман күренде аңа.* М.Хәсәнов. *Әнә ничек хозурлы була икән ул чын сөю.* Ә.Салах

**ХОЗУРЛЫК** *и.* Күңелне ял иттерә торган нәрсә, рәхәтлек. *Табигатьнең алтынсу төсләре күңелләрдә хозурлык уята, җанга рәхәтлек өсти.* Н.Хәсәнов. *Күккә ашкан чыршыларның күләгәләре үзләреннән дә озынрак булып сузылган, тирә-якта – шушы вакытта гына була торган ниндидер моңсу хозурлык.* М.Әмирханов

**ХОЗУРСЫЗ** *с.* 1) Яме булмаган, күңелсез; матур, рәхәт булмаган. *Шаһым! Туйсыз, шәрабсыз һәм уенсыз Яшел яз да булыр иде хозурсыз.* Г.Хәйям

2) Күңел тынычлыгы булмаган, бәхетсез. *Башкача булса (ягъни әйткәннәремне, үгетләремне тыңламыйча, үз көенә йөрсәң) һәр ике гаилә дә хозурсыз булыр.* М.Галләм

**ХОЗУРСЫЗЛЫК** *и.* Күңел тынычлыгы булмау күренеше, тынычлык җитмәү, бернәрсәдән ямь тапмау хәле; бәхетсез булу. *Гаиләләрнең җимерелүе, андагы хозурсызлыклар сабыйларның җаннарын өшетә, рухларын төшенкелеккә дучар итә.* Сабантуй

**ХОККЕЙ** *и. ингл. спорт* Боз өстендә, чирәмдә шайба яки туп белән уйнала торган спорт уены. *Ашап туйганнан соң, телевизорны кабызып куйды: «Бергәләп карагыз, анда хоккей бара».* Ф.Яруллин. *Сезнең Түбән Кама спорт буенча бик нык алга китте: хоккей буенча да, футбол буенча да.* Р.Миңнуллин

**ХОККЕЙЧЫ** *и.* Хоккей уйнаучы спортчы. *Әлбәттә, атаклы хоккейчы уйнаган таякны үзеңдә булдыру гаеп эш дип әйтмим, әмма журнал-китапларны җыеп барган, бүтән кадерле әйберләре белән бергә, аларны да әйбәтләп бәйләп, яңа фатирга күчерүче хуҗа кешенең шулай ачу китерерлек гаебе бар микән?* Р.Фәйзуллин. *– Зират коймасын да тоттылар, газ керткәндә дә булыштылар, юлларны, чишмәләрне дә карадылар, мәктәпкә автобус та бүләк иттеләр, хоккейчыларны да киендерделәр, – дип искә алып утырды әни кеше, горурланып.* Т.Нәҗмиев

**ХОКУК** *и. гар.* 1) Кешеләр арасындагы иҗтимагый мөнәсәбәтләрне тәртиптә тоту өчен дәүләт тарафыннан билгеләнеп, кануннарда, карарларда теркәлгән нормалар, үз-үзеңне тоту кагыйдәләре җыелмасы. *Крепостнойлык хокукы бетерелүгә карамастан, иң кечкенә гаепләр өчен, салымнарны түләмәгән өчен, крестьяннарны талчыбыклар белән кыйныйлар иде.* М.Җәлил. *Русиядә бөтен халыклар хокукы бертигез югарылыкка куелган, шуңа күрә бездә тотрыклылык, тынычлык һәм халыклар дуслыгы хөкем сөрә.* И.Хуҗин

2) Иҗтимагый төзелеш, тормыш һәм җәмәгать эшчәнлегенең берәр өлкәсенә караган дәүләт кануннары һәм карарлары җыелмасы. *Анда илдә гражданлык хокукы булган һәрбер кешегә җир маен сатудан килгән акча, бүленеп, кулларына бирелә.* Б.Рәхимова. *Мәнә бүген тагын халыкка, илгә бу үзгәрешләрнең нинди яхшылыклар алып килүен, демократик принципларның, халыкара хокук нормаларының бозылмаячагын вәгъдә итәләр.* Р.Вәлиев

3) Кануннар яки карарлар системасын өйрәнә торган фән яисә шул фәннең берәр бүлеге. *Икенче чирекнең беренче көнендә үк аларга хокук дигән яңа фән керә башлады.* В.Имамов. *«Халыкара хокук»тан экзамен бирсәм, «Бухучёт нигезләре» генә кала.* Р.Кәрами

4) Дәүләт тарафыннан бирелгән, канунлаштырылган мөмкинлек, ирек. *Тиздән Думада ирләргә күпхатынлылык хокукы бирә торган закон кабул ителәчәк икән.* Г.Галиева. *Әнә шулай, барысын да бер калыпка тигезләп, көчләп үз идеологияләренә буйсындыру – белем алырга хокуклары һәм теләкләре булган балаларның киләчәкләренә шлагбаум салу белән тиң иде ич ул.* Л.Ибраһим-Вәлиди

5) Нинди дә булса вазифа башкару, ни беләндер шөгыльләнү һ.б. өчен рәсми рөхсәт. *Бу инде аңа махсус ординатурада укырга хокук бирә.* Г.Гомәр. *Я хәлфә, я мулла, я мәзин булырга хокукы бармы?* С.Поварисов

6) Нәрсә булса да эшләргә, хәл итәргә мөмкинлек, хак. *Кайтып йөрергә хокукым бар дип беләм.* А.Гыйләҗев. *Ул бәхетне тату хокукы һәркемгә бирелә.* Д.Булатова. *Хакны әйтергә дә хокук кирәк.* Г.Морат

7) *сөйл.* Кемгә дә булса автомобиль, мотоцикл һ.б.ш. йөртергә рөхсәт бирелгәнлекне раслый торган документ, таныклык. *Шушы елда халыкара маршрутларда очу хокукы ала, ул, экипаж командиры вазифасында, дөньяның күп илләренә оча.* Г.Мөхәммәтшин. *Ул, укып, машина йөртергә хокук алды.* М.Шабаев

**ХОКУКЛЫ** *с.* **1.** 1) Нәрсәгә дә булса хокукы, хакы булган. *Ил өчен корбан булганда, Без ирекле, хокуклы... Ә тынычта халкыбызның Ireккә хакы юкмы?* И.Юзеев. *Нәтиҗәдә, дөньяда иң якты, иң хокуклы, иң бай дәүләт төзеләсе урында, моңа тикле кешелек тарихы белмәгән иң хурлыклы, иң хокуксыз, иң хәерче дәүләт барлыкка килде.* З.Мәхмүди

2) *лингв.* Мөнәсәбәтле. *Шунлыктан алар тигез хокуклы җөмлә кисәкләре түгел һәм бер синтаксик вазифа башкара алмыйлар.* Л.Мирсәяпова

**2.** *рәв. мәгъ.* Хокуклы рәвештә, хокукы булган килеш. *Татарстан ССРда татар һәм рус телләренең дәүләт теле сыйфатында тигез хокуклы кулланылуы, башка милләтләрнең телләрен саклау һәм үстерү гарантияләнә.* Ш.Алпар. *Хокуклы яшәү. Хокуклы кулланылу*

**3.** *хәб. функ.* Хокукы бар. *Мөхәммәдәмин анасына ничек җавап биргәндер, анысы билгесез, тик ул вафат булган хәләл җефете урынына янә дә никахка керергә хокуклы.* М.Әмирханов. *Ул кеше үзенең ризасызлыгы белән судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы, ә инде аның мөрәҗәгате канәгатьләндереләме, юкмы – анысы хөкем эше.* Л.Зарипова

**ХОКУКЛЫЛЫК** *и.* Хокуклы булу, билгеле хокукка ия булу хәле. *Ул теге яки бу фанатизмга каршы, халыкларның һәм дәүләтләрнең аңлашып, тату яшәүләрен тели, тигез хокуклылыкны, яхшы күңеллелекне яклый.* Т.Әйди. *Гаяз Исхакый бер милләтнең икенче милләткә буйсынып яшәвен гайре табигый күренеш дип саный, һәр халыкның – зурмы ул, кечкенәме – үзенчә, ирекле яшәргә хаклы булуын яклый, милләтләр арасында тигез хокуклылык өчен көрәшә.* Х.Миңнегулов

**ХОКУКСЫЗ** *с.* **1.** 1) Сәяси һәм гражданлык хокукларыннан мәхрүм ителгән. *Иҗат ул, бәлки, хокуксыз халыклар хокукын даулап, бар дөньяга аваз салудыр?* Р.Вәлиев. *Анда син кеше булып керәсең, бернинди хокуксыз мәхбүс булып чыгасың.* З.Мурсиев

2) Нәрсәгә дә булса хокукы, хакы булмаган. *Үзенең бу кадәр бәхетсез һәм хокуксыз булганы өчен, юл читендә бер-берсенә орынып үскән өч орылы каеннан да оялып куйды ул.* А.Хәлим. *Мин баш мөхәррир саналсам да, хокуксыз «баш».* Н.Гыйматдинова

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Хокуклары булмаган килеш. *Эстетик вазифаны көчәйтү белән бер үк вакытта, Г.Тукай үзенең әсәрендә, бик оста итеп, халыкның җәбер-золым эчендә хокуксыз яшәвен, кешелек дөньясы туплаган сәнгать һәм культура хәзинәләреннән мәхрүм булуын да күрсәткән.* Л.Җамалетдинов. *«Нишләргә?» дигән сорауны төрләндереп, хокуксыз йөргән бер мәлдә, кемдер миңа киңәш итте: «Паспорт алу өчен генә булса, Уфага бар, ике генә имтихан бирәсең дә...» – дип, техникум исемен әйтте.* М.Галиев

2) Хакы булмый торып, хаксыз рәвештә. *Хокуксыз йөртү. Хокуксыз куллану*

**3.** *и. мәгъ.* Ирексез, кемгәдер яки нәрсәгәдер бәйле кеше. *Шәһәр күзгә күренеп үсә, аны, нигездә, тоткыннар һәм хокуксызлар төзи.* Ф.Бәйрәмова. *Ә күпләрнең инде анысы да юк, Хокуксызлар үрчи елдан-ел.* Ф.Гыйләҗев

**ХОКУКСЫЗЛЫК** *и.* Хокук булмау күренеше, хокуксыз булу хәле. *Сары йорт үзе исә – хокуксызлык, чарасызлык, кеше кадере булмауның символы.* А.Гыйләҗев. *Чикнең теге ягында ачлык, изү, изелү, золым, хокуксызлык, хәерчелек.* В.Юныс

**ХО́ЛДИНГ** *и. ингл. экон.* Башка предприятие акцияләренең өлешчә яки тулы хуҗасы булып, аның эшчәнлеген контрольдә тота торган предприятие, фирма яки акционерлык җәмгыяте. *Һәм Сөмбелә җаваплылыгы бик үк чикләнмәгән «Ташлы» фирмасы гендиректорына шундый киная белән карап алды ки – тегесе, урындык аркасына сеңеп, юка гәүдәсен холдинг президенты кулагәсенә яшерде.* К.Кәримов. *Бөтен җирле телерадиокомпанияләр холдингка берләште.* Г.Шәйхи

**ХОЛЕ́РА** *и. лат.* Тән температурасы төшү, косу, эч китү кебек билгеләре булган йогышлы авыру; ваба. *Монгол биләмәләре аша холера да узмады, алар өстенә хлорофос та сипмәделәр.* А.Хәсәнов. *Тоткыннарның үлемкитеме башлыкларны борчымый икән, холера, тиф шикелле йогышлы афәтләрдән генә куркалар, ди.* М.Әмирханов

**ХОЛЕ́РИК** *и. лат.* Тиз кабынып китүчән, кызу канлы, энергиясе ташып тора торган темпераментлы кеше. *Гыйззәтуллин – меланхолик, Әлтафи – флегматик, Зарифуллин – холерик, имеш.* М.Мәһдиев. *Ул кем: кызу табигатьле холерикмы, әллә шат күңелле, хәрәкәтчән, тышкы тәэсирләргә җиңел бирешүчән сангвиникмы?* Р.Кәрами

**ХОЛЕСТЕРИН** *и. гр. биол.* Стероидлар классына керә торган органик кушылма (кешеләрнең һәм хайваннарның күзәнәк мембраналарында була). *Тик хәзер инде, аларда холестерин күп дип, өстәвенә симертә дип, медицина кушмаганга күрә генә тыелыбрак ашарга туры килә...* М.Әмир. *Шәһәрнекеләр сөт-каймак ашамый, зарарлы, холестерин күбәя, диләр.* Н.Гыйматдинова

**ХОЛЕСТЕРИНЛЫ** *с.* Составында холестерин булган. *Шунлыктан әледәнәле тикшеренергә: көндәлек табыннан майлы һәм холестеринлы ризыклар санын киметергә; тәмәкене ташларга; ябыгырга; физик активлыкны арттырырга кирәк.* Ватаным Татарстан

**ХОЛЕСТЕРИНСЫЗ** *с.* Составында холестерин булмаган. *Табиблар куян итенең яхшы үзләштерелүе, аксымның югары дәрәҗәдә, холестеринсыз булуы аркасында балаларга, сабый имезүче хатыннарга, ашказаны, йөрәк-кан тамырлары авырулары белән интегүчеләргә бик файдалы булуын әйтә.* Ватаным Татарстан

**ХОЛЕЦИСТИТ** *и. гр. мед.* Үт куыгы ялкынсыну авыруы. *Бу эшне ул соңыннан «Хроник төстәге холецистит һәм аллергия» темасына докторлык диссертациясе язганда ныклап өйрәнергә тотынды.* Л.Ихсанова. *Ипохондрия, холецистит, гастрит – бөтенесе бергә булса, әлбәттә, баш әйләнә инде ул.* Р.Батулла

**ХОЛОДИ́ЛЬНИК** *и. рус к.* **суыткыч 1.** *Безнең өй булса, холодильник сатып алсак, мин дә шулай тәмле итеп ризыклар пешерер идем...* А.Гыйләҗев. *Холодильник белән кер юу машинасы бирсәгез дә риза.* К.Кәримов

**ХОЛЫК** *и. гар.* 1) Кешенең үз-үзен тотышында чагыла торган иң тотрыклы психик сыйфатлар җыелмасы; кешенең табигате, фигыле; характер. *Гөлфинур холкы белән тиктормас чая кыз булганга, бу шаярулар аңа килешеп тора, тик Рәфиснең бүгенге халәте кыз каршында гына түгел, хәтта үз алдында да яңа, танымаслык иде.* А.Вергазов. *Зирәк зиһен, үткен фикер, күркәм холык, тулы иман бир!* А.Хәлим

2) Гадәт; кешенең үз-үзен тотышы. *Эзләнер-чокчыныр да холкыңнан, фигылеңнән бер-бер чатак казып чыгарыр.* А.Гыйләҗев. *Фатиха аңа аучы атадан өйрәнеп калган тәҗрибәсен тапшыра: табигать балаларының халәтләрен, холыкларын аңлата, кешеләрнең үз куллары белән йортлар, өйләр төзеп, искиткеч бакчалар үстерүләре турында сөйли.* А.Нәҗми

3) Билгеле бер максатка ирешү, сынауларны җиңү өчен ихтыяр көче, ныклык, үҗәтлек. *Талант бер хәл, өстәп – ихтыяр, сугышчан рух, холык бармы анда?* Р.Фәйзуллин. *Холык бар ул кызда!* Н.Кәримова

4) *күч.* Нәрсәнең дә булса (мәс., табигать күренешләренең) билгеле бер сыйфаты, үзлеге, характеры, кәефе. *Давыл купканда да, диңгез холкын күрсәткәндә дә, таулар дәшми.* В.Нуруллин. *Көннең холкын белмәссең: саран гына елмайган кояш артыннан җәлт кенә болыты да килеп чыга, ә дигәнче түгелеп тә китә.* А.Әхмәтгалиева // Нәрсәнең дә булса үзенчәлекле билгеләре, сыйфатлары җыелмасы. *Ак кардагы ак чәчәкнең дә үз төсмере, үз холкы бар.* Шәһри Казан

◊ **Холкына килү** Кәефе булу, холкына туры килү, ошату. *Ел саен диярлек хатын алыштырган, холкына килмәсә, куып та чыгарган Инәкантәй – бер караганда инәсе белән үз йортында, бер караганда Нәстүкләрдә – ике йорт арасында яшәп йөрегән.* А.Хәлим. **Холкы үзе белән** Холкы тотрыклы булмау, тиз кызып китүчән, кызу канлы, үзсүзле булу. *«Холкы үзе белән инде», – дип кисәткән булсалар да, «Агромастер» ЯАҖ җитәкчесе Илгиз Исламовның кабинетына кергәндә, шик-шөбһәләрне ишегалдында ишеткән тимер җыры таратты да бетерде.* Шәһри Казан

**ХОЛЫКЛЫ** *с.* 1) Теге яки бу холыкка ия булган, шундый характерлы. *Әле моннан бер генә атна элек һәр сүзендә шатлык, күңеллелек яңгырап торган шаян холыклы офицер кинәт картаеп киткәндәй булды: ябыкты, сүзгә саранланды, башын түбән иеп йөри башла-*

*ды.* Г.Кутуй. *Вәли абый гәүдәгә безнең әтидән дә зуррак, кырыс холыклы, нык куллы, бик көчле кеше иде.* Г.Бәширов

2) *сөйл.* Холкы яхшы булган, характеры уңай булган. *Сәлим бай үлгәч, аның хатыны ятим калган иде. Бик холыклы нәрсә.* Г.Ибраһимов. *Барысы да яхшы иде, тик шулай насыйп булгандыр инде: картлыгымны Мулла авылында туып үскән бик холыклы һәм акыллы Кадрия Гайнуллина белән каршылыйм.* Э.Шәвәлиева

**ХОЛЫКНАМӘ** *и. гар.-фар. к.* **характеристика**. *Әлфия апа, син үзең белән сәхнәдәш булган артистларга кыскача гына холыкнамә биреп чык.* Р.Батулла. *Семиостров волостеннан кайткач, Харисов белән Фәйзуллиннан сиңа холыкнамә – характеристика сорап алачакбыз.* Ф.Сафин

**ХОЛЫКСЫЗ** *с.* 1) Авыр холыклы. *Әмма безнең әти алай холыксыз кеше түгел, әнинең дорфалыгын да елмаеп кына уткәреп җибәрде.* А.Гыйләҗев. *Ләкин чамадан тыш холыксыз Хәкимне бала мәхәббәте генә дә үзгәртә алмады.* Э.Шәрифулина

2) Кызу канлы, көйсез, кире. *Могҗиза белән абый әйләнеп кайткан тәкъдирдә дә, мин бүтән монда тормас идем, чөнки холыксыз җиңги белән үзсүзле Кәтүктән күңелем тәмам бизде.* Н.Гыйматдинова. *Аның дуамал, холыксыз Тимурын да фәрештә дип уйлаучылар бардыр, бәлки?* Р.Габделхакова

3) Тыңламый торган, кире, көйсез (хайваннар тур.). *Кытыгы басылып җитмәгән холыксыз айгыр, дилбегәнең кем кулында икәнлеген сизеп, кушаяклап сикерә-сикерә, тузанлы юлдан авыл башына таба томырылды.* З.Хөснияр. *Ә менә Караборын холыксыз хайван булып чыкты.* Л.-Х.Таналин

**ХОЛЫКСЫЗЛАНУ** *ф.* 1) Холкы, характеры бозылу, начарлану. *Сугыштан бик холыксызланып кайтты.* Р.Батулла. *Тора-бара бөтенләй холыксызланды иркә кыз: «Сөйләшә белмисең кеше белән сөйләшмә, тыңлап кына тор башкаларны, минем иптәш кызлар килгәндә чыгып басма бүлмәгә карачкы төсле, кысылма безгә», – дип, авызын ябарга уйлады әнисенең.* К.Кара

2) Кызып китү, ярсу, дулау, кәефсезләнү, ачулану. *Исхак иртә белән пожаркага чыгып киткән иде, шуннан корт чаккан баладай холыксызланып кайтты.* Т.Галиуллин. *Илсөяр, юкка-барга холыксызланган чакларда, һичбер юату чарасын тапмаса, юк эшен бар итеп, өйдән чыгып китү ягын карады.* Ф.Яруллин

3) Киреләнү, капризлану, тәртипсезләнү. – *Бу бала нигә болай холыксызлана, сәбәбен һич аңлый алмыйм, – дидем, үземне күптән борчыган сорауга җавап табасым килеп.* Р.Мөхәммәдиев. *Камил кызның чәбәләнүенә, холыксызлануына аптырап, таный алмыйча карап торды.* Ф.Бәйрәмова

4) *күч.* Үзен бөтенләй башкача тоту, күрсәтү, көтелмәгән хәлләр, вакыйгалар белән гаҗәпләндерү. – *Апатит тавының хуҗасы кайчакларны бик холыксызлана, сак булыгыз, – дип кисәтеләр алар.* А.Хәсәнов. *Кеше гөнаһларыннан арыган җир-ана холыксызлана.* М.Галиев

**Холыксызлана бару** Торган саен ныграк холыксызлану. *Гарипләрнең, хасталарның көйсезлеген, тора торып холыксызлана баруын Бакыйдан да яхшырак аңлаган кеше бар микән?* М.Маликова. *Мөхәммәтҗан торган саен холыксызлана бара.* Ф.Сафин

**Холыксызлана төшү** Бераз холыксызлану, тагын да холыксызлану. – *Мине кемгә саныйсыз! – дип кычкырды ул, холыксызлана төшеп.* Кызыл таң

**Холыксызланып алу** Бераз вакыт холыксызлану. – *Гаиләмә, ике кызым һәм улым Шарльгә исәнлегемне генә белгертү өчен дә җанымны бирер идем! – дип, вакыт-вакыт холыксызланып ала.* А.Хәсәнов. *Шулай берничә көн холыксызланып алганнан соң, мич тагын җайга салына – өйне май кебек итеп җылыта.* З.Зәйнуллин

**Холыксызланып бетү** Тәмам холыксызлану. *Соңгы айларда бөтенләй холыксызланып бетте әле ул бала, һич танырлык түгел.* Р.Вәлиева

**Холыксызланып йөрү** Һәрвакыт холыксызлану. *Акча сорап та бирмәсәләр, холыксызланып йөрүен дә күрәләр.* Безнең гәҗит

**Холыксызланып китү** Соңгы арада холыксызлана башлау. *Бу арада бурлы бия бик артык холыксызланып киткәнгә, мин аның янына барырга курыктым.* Г.Ибраһимов. *Ә инде холыксызланып киткәндә, ара-тирә узынып, хатыннарын әрләп, ялчыларын җәберләгәннән соң, түбәгә менгән дә гомер буе сөйрәп йөргән чыбыркысына карап торган.* Н.Гариф

**Холыксызланып кую** Кинәт, көтмәгәндә холыксызлану; бер тапкыр холыксызлану. *Язмыш дигән нәрсә кайчакларны бер дә юктан гына холыксызланып куеп, гел нахакка гына каһәрләгән чакларны да, безнең мөселман баласы тирбәлгән бишеген, сөргән җирен, туган илен калдырырга мәҗбүр булса да, динен үзеннән калдырмаган.* А.Хәсәнов. *Чатаклыклар килеп чыкса, холыксызланып та куя.* Т.Нәҗмиев

**Холыксызланып тору** Гел, һәрвакыт холыксызлану; әле, хәзер холыксызлану. *Әтү, хатын-кыз шикелле, холыксызланып торган буласың.* В.Нуруллин

**ХОЛЫКСЫЗЛЫК** *и.* Холыксыз булу, холкы начар булу. *Аның әнкәсе Фәтхия карчык һәркайчан, Сабира кодагыйның холыксызлыгыннан зарланган саен, күз яшен сөртеп сөйли иде: – Илаһым хуҗам, ичмасам Шиһабетдин коданың гомерен озын кыл.* Г.Ибраһимов. *Житмәсә, шуларның холыксызлыгына түз, имеш, тазалыгыңны бетер.* К.Кара

**ХОЛЫК-ФИГЫЛЬ** *җый. и.* Холык һәм гадәтләр җыелмасы. *Димәк, дөнья бер генә калыптан яратылмаган, димәк, күпме кеше – шуның кадәр холык-фигыль.* Н.Әхмәдиев. *Бу өч егеттә уртак сыйфатлар да җитәрлек, үзләренә генә хас холык-фигыльләре дә төсмерләнә.* С.Шәрипов

**ХОНСА** *и. гар.* **1.** Ике җенесле кеше яки хайван; кызтәкә, гермафродит. *Габдулла күңелле көлеп җибәреп: «Коръән шәрифтә «Адәм ыруында беренче – ирләр, алардан соң үсмерләр, алардан соң – малайлар, шуннан сон – хатын-кызлар, алардан соң – хонсалар», – диелгән».* Р.Вәлиев

**2.** *с. мәгъ.* Сакалы үсмәгән яки сакал төкләре бик сирәк булган; күсә. *Сөен тутай Җан Галинең ир-егет буларак гайрәтсез икәнен дә, хонса йөзле икәнен дә ишетеп белә иде.* Р.Батулла // Гайрәтсез. *Хонса ир*

**ХОР** *и. гр.* 1) Вокаль әсәрләрне күмәкләп башкаручы җырчылар коллективы. *Һәм хор шуның белән таралды, бетте.* М.Мәһдиев. *Опера театры белән филармониядән илле кешелек хор килә, оркестр килә.* Ф.Баттал

2) *сөйл.* Вакытлыча берничә җырлаучыдан оешкан төркем; билгеле бер урында бергәләп җырлаучылар. *Шуңа күрә табын бер зур хорга әйләнә торган булды.* И.Юзеев. *Исерекләр хоры үтеп киткәч, Сөмбелә, кабаланып, гармунчыны ашыктырды.* К.Кәримов

3) Җырчылар коллективы башкару өчен язылган музыкаль пьеса, әсәр.

*Драманың башындагы ике пәрдәсендәге хорда «Галиябану», «Һаваларда йолдыз», «Газизәкәй» көйләре бик матур җырланып, япон караучыларга азияле икенче бер халыкның үзенекенә охшаган музыкасы бик зур тәэсир калдырды.* Г.Исхакый. *Спектакльдә уйнаучы артистларны хорда яисә аерым арияләрдә җырларга өйрәтү бер дә ансат булмады.* Р.Низамиев

4) Күп, төрле тавышларның бер вакытта, берьюлы яңгырашы. *Кученгән авылның ташландык инешендә ятим калган гыйшыклы бакалар хоры уйларны бүлдерми бүлдерүен.* К.Кәримов. *Кояш бик ярамаган курортчылар нарат төпләренә япмаларын җәя дә көннәр буе һава сулап, өстә, куе ылыслар арасында көн-төн зеһ-зеһ сайраучы диңгез чикерткәләренең хорын тыңлап ята.* Д.Булатова

5) *куч.* Күмәкләп сөйләү, уку, кычкыру һ.б.ш. *Тыштан «Яшәсен Насретдин хан» дигән хор ишетелә.* Н.Исәнбәт. *Ә без тау башыннан хор белән такмак әйтәбез: «Хәйри балта, пычак кайрый, Кайраса да үтми, Касыйм гына җитми...»* М.Мәһдиев

**ХОРАЛ** *и. гр.* 1) Төрле тавышка җырлый торган чиркәү хоры (аеруча протестантларда һәм католикларда киң таралган). *Хорал башкаруында җыр тыңлау*

2) Шул формада язылган музыкаль әсәр. *Протестантларда хорал өстенлек итә, ул махсус җырчылар, шулай ук диндарлар (мәхәллә кешеләре) тарафыннан орган яисә башка музыка кораллары аккомпанементында җырлана.* К.Гыйззәтов. *Бах чоры музыкасы да, грегориан хораллары да, популяр музыка да, фольклор да берьюлы яңгырый.* Сәхнә

**ХОРАФАТ** *и. гар.* Нигезсез мифик, дини һ.б. уйдырма, юк-барга ышану. *Халыкның рухына хорафат сеңдерү уенда булсаң, ул нәрсәләрне авылда бик шәп эшләп була.* Һ.Такташ. *Мәдрәсә стеналары эчендә күпме хорафат, дини риваять ишеткән, диңгез дәһшәтеннән болай да коты алынган татарның шуларны күргәч рухи халәтен, куркуын, исән-имин йөреп кайткач ни рәвешле сөйләячәген күз алдына китерик.* М.Мәһдиев

**ХОРАФАТЧАН** *с.* Хорафатка, юк-барга ышанучан. *[Зәйтүнә], үзенең ялгызлыгын, үзенең хорафатчан җанын җиңә алмыйча һәм ата-ана сүзеннән чыгуны үзе өчен хурлык һәм гөнаһ санап, үзенең иң көчле бер тойгысын авызлыкларга, мәңгегә үзендә күмеп калдырырга карар кылды.* Ф.Хөсни. *Аңладым. Син хорафатчан түгел.* З.Хәким

**ХОРАФАТЧАНЛЫК** *и.* Хорафатчан булу сыйфаты, хорафатларга ышанучанлык. *[Зәйтүнә], үзенең хорафатчанлыгы аркасында, Сәлмән малаена чыгарга ризалык биргән булса да, бернәрсәгә дә карамыйча, Сәфәргали янына тегермәнгә качарга булды.* Ф.Хөсни

**ХОРАФАТЧЫ** *и.* Хорафатларга, юк-барга ышанучы кеше. *Димәк, илдә хорафатчылар саны кимемәгән, ә бәлки арткандыр да әле.* А.Тимергалин

**ХОРАФАТЧЫЛ** *с.* 1) Төрле хорафатларга нигезләнгән; хорафаттан гыйбарәт булган. *Аерым даирәләрдә, хатын-кызның җаны булмый, дигән хорафатчыл караш таралган.* А.Тимергалин. *Аның фаразлавынча, урыс староверларының примитив яшәү рәвеше һәм үтә сәер урыс миллионеры Стерлиговның хорафатчыл идеяләре җәмгыятьне дөрес юлга чыгара, ахырзаманның килүен тоткарлый алыр иде.* Татарстан яшьләре

2) *к.* **хорафатчан**. *Болай үзе әнине бик хөрмәт итсә дә, аның хорафатчыл булуын, коткыга тиз бирелүен бер дә өнәми.* Ф.Хөсни. *Ничек гаҗәп тоелмасын, хорафатчыл кешеләр, тынычлану өчен, ахырзаман идеясенә җитди карый.* Безнең гәҗит

**ХОРЕО́ГРАФ** *гр. и.* 1) Хореография остасы; хореография белгече, биюче. *Без – булачак хореографлар.* Т.Галиуллин. *Ансамбль хореографлар белән тулыланса да, җырчылар кирәк әле.* Ватаным Татарстан

2) Хореография укытучысы; биюләр, спектакль яки балет композицияләре куючы; балетмейстер. *Шунлыктан театрда хореограф хезмәте бигрәк тә музыкаль жанрга караган спектакльләрдә мөһим роль уйный.* Д.Гыймранова. *Әнә шул «юк»лыклар бәгырьгә үткәнгәме, минем бер чын тренерны, чын хореографны күрәсем килә иде.* М.Садыйков

**ХОРЕОГРА́ФИК** *с.* Хореографиягә мөнәсәбәтле, хореографиягә бәйле. *Репертуарын популяр халык җырлары эшкәртмәләре, --- заманча темага такмаклар, хореографик миниатюралар тәшкил иткән Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле өчен күп әсәрләр язылса.* Ф.Арслан. *Концертта шулай ук күп кенә җирле вокаль һәм хореографик ансамбльләр дә катнашачак.* Ватаным Татарстан

**ХОРЕОГРА́ФИЯ** *и. гр.* 1) Бию сәнгате. *Гарәп хореографиясенә хас рәвештә биюченең һәр мускулы уйный, күкрәкләр, ботлар дерелди.* Т.Әйди. *Әйтергә кирәк, аның мәхәббәте, нигездә, хореография алымнары белән күрсәтелгән.* А.Габәши

2) Сәхнәгә куелган бию; бию элементлары; төрле биюләрдән торган сәхнә әсәре. *Сәйдәш музыкасы, заманча хореография, «тере оркестр», зәвыклы сәхнә бизәлеше тамашачыны бик тиз үз дулкынына ияртә, аның игътибарын яулый.* Фәнни Татарстан

3) Биюләр һәм балет спектакльләре әзерләү, кую сәнгате, фәне. *Ә менә махсус фәннәр – сәхнә теле, актёрлык осталыгы, сәхнә хәрәкәте, вокал, хореографияне уку кирәк.* З.Гыйльметдинова. *Ә Рәзимә, үз уйларына чумып, безне яшьлегенә – яңа тормыш башланырга торган елларга алып китте: «Мин – хореография, ә ул оркестр булегендә укый иде».* И.Фәйзрахманов

**ХОРМЕ́ЙСТЕР** *и. гр.-нем.* Хор җитәкчесе, дирижёры. *Безне Лима Кустабаева атлы яшь хормейстер белән таныштырдылар.* Л.Шагыйрьҗан. *Хормейстерлар хәзер күп, әмма чын профессионаллар бармак белән генә санарлык.* Р.Миңнуллин

**ХОРТУМ** *и. гар.* Филдә һәм кайбер башка хайваннарда сулыш алу, сизү һәм нәрсә дә булса эләктереп алу өчен хезмәт итә торган озынча әгъза. *Берсе филнең озын борынын – хортумын капшап караган: «Бу бик юан, бик зур елан икән», – ди.* М.Хәсәнов. *Шул ук вакытта икенче мичтән түшәмдәге рельслар буйлап килеп җиткән ачкүз кран фил хортумыдай озын борыны белән әзер сыекчаны махсус мичкәгә суыра.* Т.Галиуллин

**ХОРЧЫ** *и.* Хор җырчысы. *Җитәкчеләре кул биргәнне күреп, узып баручы һәр хорчы Шостаковичка кул биреп исәнләшә башлый.* Р.Батулла. *Беразга тын торганнан соң, ректор сәхнәдәге хорчылар хакында да искәртеп узды, шушы хор коллективының университет горурлыгы булуын ассызыклап алды.* Ф.Яхин

**ХОСУС** *и. гар. кит.* Очрак, мәсьәлә; аерым деталь. *Инде Гаяз Исхакыйның «Зиндан»ыннан бу хосуста өстәмә дәлил алабыз.* Р.Әмирхан. *– Бу кадәресе сиңа зарури түгел, – дип, бу хосуста үзенең сай йөзгәнлеген сиздерде дә чыбыгын чыжлатып алды.* С.Поварисов

**ХОСУ́САН** *рәв. гар. кит.* **1.** Бигрәк тә, аеруча, аерым алганда. *Иң зур про-*

*блемаларның берсе: әдәбият белеменең гомумән, татар әдәбияты белеменең хосусан үз методологиясен булдыру зарур.* М.Хәсәнов. *Моның чагылышын без хосусан татар-яһүд мөнәсәбәтләрендә күзәтәбез.* Р.Сафин

**2.** *кер. сүз. функ.* Аерым алганда, аеруча, атап әйткәндә. *Ул ыруг, хосусан, Г.Ибраһимовның «Казак кызы» хикәясендә искә алына.* Р.Әхмәтьянов. *Хосусан, «гыйлем әһеле киемен киенеп, караңгылык ишекләренә ябышып ятучы кешеләрдән курыктым» дип яза Курсави «Туры юлга өндәү китабы»нда.* Р.Батулла

**ХОСУСИЯТ** *и. гар. кит.* Үзенчәлек, аермалык. *Игътибарга лаек бер хосусияте – галимнең кызыксыну, тикшеренү даирәсенең киңлеге.* Т.Әйди. *Андагы бәхәсле, кимчелекле яклар да халкыбызның «үсү, алга үрләү» хосусиятләре белән билгеләнә.* Х.Миңнегулов

**ХОСУСЫЙ** *с. гар.* **1.** 1) Аерым, махсус; нәрсәнең дә булса аерым кисәген, өлешен тәшкил итә торган. *Шулай да бу хосусый тантана гына түгел.* Р.Фәйзуллин. *Сүз бары кайбер хосусый күренешләрнең дә нигезләрендә социаль-иҗтимагый, сәяси-идеологик сәбәпләр ятуы хакында.* Р.Вәлиев

2) Аерым бер кешегә, шәхескә генә карый торган, шуңа гына мөнәсәбәтле, шәхси. *Кешенең кайбер хосусый сыйфатларын билгели торган физиологик-табигый факторлар: мәхәббәт – табигать бүләге.* И.Бәширова

3) Аерым кеше өчен билгеләнгән, махсус. *Бер үк вакытта үзенә дә, хосусый дәресләр алып, өлгергәнлек аттестатына хәзерләнү мөмкинлеге булуы беленә.* М.Хәсәнов. *Анда хосусый мөгаллимнән ике ай кадәр русча укыдым.* Р.Зарипов

4) Иҗтимагый тормыштан, коллектив эшчәнлектән читтә булган, аның белән бәйләнмәгән, аерым. *Ул ябык актив җыелышы иде, хосусый кешеләр алдында андый эшләр турында сөйләмиләр.* Т.Гыйззәт

5) Шәхси милек биләү, аерым хуҗалык итү һәм шуңа ярашлы иҗтимагый-икътисади мөнәсәбәтләр белән бәйләнгән. *Иң әүвәл бу җирнең әлегә төгәл статусы билгеләнмәгән: дәүләтнекеме, әллә хосусыймы?* Р.Фәйзуллин. *Коттедж сиңа хосусый милек итеп билгеләнгән, машина да синең исемгә язылган.* З.Хәким

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Махсус рәвештә. *Һәр атна кич күрше муллага хосусый үзе барып, үлекләр өчен дип садакасын да биреп килеп, елына бер мәртәбә голәма мәҗлесе ясап, тирә-яктагы муллаларны, байларны җыеп ашатып озата иде.* К.Тинчурин

2) Аерым, мөстәкыйль рәвештә. *Виргасов, язгы айларны шәһәрдә кайбер фәннәрдән хосусый укып хәзерләнеп ятуы сәбәпле, аңа да бара алмады.* Һ.Такташ. *Димәк, иске татар әдәби телендә урын алган бу вариантның хосусый яшәвенә махсус рәвештә игътибар итеhelp.* Фәнни Татарстан

3) Аеруча. *Йосыф та үзенең «милли шагыйрь» булып китүеннән хосусый ләззәтләнде.* Ф.Әмирхан

**ХОСУСЫЙЛЫК** *и.* 1) Хосусый булу хәле, сыйфаты. *Ә инде кульязма китапларда ничектер хосусыйлык, әдипкә һәм укучыга якынлык күзәтелә.* Х.Миңнегулов. *Безне хосусыйлык канәгатьләндерми.* Кызыл таң

2) Хосусый милекчелек. *Хосусыйлык, шәхси бизнес тормышны аякка бастырачак, диләр.* Ә.Хәсәнов. *Ә инде дөресен генә әйткәндә, гадәттән тыш юан бу ханымны иртә таңнан түбәгә менәргә үзен мал иясе итеп сизү, хосусыйлык тойгысы мәҗбүр итте.* Җ.Ильясов

**ХОСУСЫНДА** *бәйл. иск.* Турында, мәсьәләсендә. --- *хатын-кызга карашы хосусында әллә никадәр сораулар бирергә дә хәзерләнгән иде.* Безнең мирас. *Әмма бу балаларга сабак укыту хосусында сиңа яхшырак тәрбия бирәсем бар.* Ватаным Татарстан

**ХОТ-ДОГ** *и. ингл.* Уртасына сосиска һәм тәмләткечләр салынган озынча күмәчтән гыйбарәт ашамлык. *Яраткан азыгы – хот-дог, люля-кебаб.* Х.Ибраһим. *Дүрт-биш ай йөкче булып эшләп, бераз акча җыйгач, хот-дог ясый торган аппарат сатып ала.* А.Сабирова

**ХӨББЕНӘФЕС** *и. гар. иск.* Минминлек, үз-үзен ярату, эгоизм. *Чөнки бу минем азрак хөббенәфесемә барып кагыла иде.* Г.Рәхим. *– Холоп?! – Бу сүзләрне ишеткәч, хөббенәфесле Шаһгалинең башы әйләнеп китте.* З.Мәхмүди

**ХӨҖРӘ** *и. гар.* 1) *иск.* Мәдрәсә шәкертләре яши торган бүлмә, торак. *Фарукҗан, монда байбәтчәләр, төшемле урын сагалап еллар буе мәдрәсә хөҗрәсендә аунап яткан пишкадәмнәр ишле икәнлеген чамалап, иптәшенең сүзгә катнашуына пошынмый булдыра алмады.* Т.Әйди. *Йортның тирәюнендә шәкертләр өчен бик күп хөҗрәләр бар.* Х.Миңнегулов

2) Нинди дә булса, гадәттә бик ярлы яки бик кечкенә сыеныр урын. *Бу бүлмә – Сөмбеләнең хөҗрәсе, аның зонасы, бүлмәдәге һәр почмак аның бик күп күз яшьләренә шаһит.* А.Гыйләҗев. *Бакый, тиз генә үз хөҗрәсенә кереп, соңгы ике шакмак шикәрен ала да чакырган җиргә китә.* Р.Батулла

**ХӨКЕМ** *и. гар.* 1) Кем яки нәрсә турында гомуми фикер, бәяләмә, карар. *Ул, объектив судья кебек, һәр якның дәлилләрен үлчәүгә салып, гадел хөкемен соңыннан белдерергә ярата.* А.Вергазов. *Кыз энесен җәлләү хәсрәтеннән котылса да, караклык бәласеннән әле котылмаган, ул инде өйдәгеләрнең һәм Вера апасының хөкемен көтә иде.* Ф.Җамалетдинова

2) Кешеләр арасында чыккан бәхәсләрне хәл итү һәм җинаятьләрне тикшерү эшләрен башкара торган дәүләт органы; суд (*1 мәгъ.*). *Һичкем ни булганын аңларга өлгерә алмады, мин: – Киряксә, мине хөкемгә чакыртырсыз! – дип чыгып киттем.* Г.Ибраһимов. *Өченче тапкыр сез хөкем каршында, һаман сез үзегезгә нәтиҗә ясамагансыз.* Р.Батулла

3) Җинаять эшләре һәм һәртөрле бәхәсләрне тикшерү эше, мәхкәмә эше, суд процессы. *Нәгыймә килеп кергәндә, хөкемнең барышы менә шул җирдә иде.* Г.Ибраһимов. *Судьялар, прокурор һәм адвокатлар хөкемдә булучыларга, шаһитларга сораулар бирәләр.* Р.Фәизов // Төрле бәхәсләрне хәл итү һәм кемнең дә булса кылган гамәле, гаебе өчен җәмгатьчелекнең, кешеләр төркеменең, халыкның карар кабул итүе; халык суды. *Күләме вак-төяк булса да, мәшәкате зурдан – барыбер фаш итәсе, җәмәгатьчелек хөкеменә тартасы була.* Т.Әйди. *Икенче көнне Хөрмәтулланы халык хөкеменә алып чыктылар.* С.Поварисов

4) Берәр төрле эш буенча суд карары. *Ата суд хөкемен көтә, ашыкмый, әле судтан соң да тиз генә башка кешегә ярәшеп куймый, Хәдичәне дә артык көчләми шикелле.* Р.Рахман. *Әлеге вакытта ул тикшерү изоляторында хөкем көтеп утыра.* М.Кәбиров // Җәза. *Ризамын мин халкым хөкеменә.* Ф.Бурнаш

5) *җый.* Судьялар, хөкем итүчеләр. *– Хөкем килә! Торыгыз! – дигән каты тавыш белән бөтен зал гөж-ж итеп аякка басты.* Г.Ибраһимов. *Бераздан кыңгырау шалтырады, һәм тәртип караучының: – Хөкем килә! Торып басыгыз! – дип кычкырган ачы тавышы ишетелде.* М.Галәү

6) Кемнең яки нәрсәнең карары, ихтыяры, ирке. *Сәет аның ниятен аңлады: йортны эчендәге кешеләре белән бергә ут хөкеменә тапшыру.* Т.Галиуллин. *Берәүне дә кыерсытмыйча, каршылыклы фикерләребезне Аллаһның үз хөкеменә тапшырып, бер-беребезне хөрмәт итеп, татулыкта яшәргә өйрәнсәк иде.* Шәһри Казан

7) Берәр затның игътибары, хозуры, күз алды. *Иҗат җимеше халык хөкеменә куелгач, шагыйрьгә, рәссамга, композиторга, җырчыга, артистка рәхимле укучылары, тыңлаучылары, тамашачылары шау килеп рәхмәтләр яудыралар, дөнья яңгыратып кул чабалар, дан-шөһрәт ширбәтен тустаганның зурысы белән эчерәләр.* Г.Әпсәләмов. *Спектакльне тамашачылар хөкеменә тапшырыр вакыт килеп җиткән, режиссёр да, Батырҗанны уйнаучы артист та композиторны ашыктыра, Сәйдәшев үзе дә бик борчыла.* Р.Батулла

◊ **Хөкемгә тарту** Судка бирү, суд аркылы җаваплылыкка тарту. *Гайни әйтүе буенча, бу явыз җинаятьнең оештыручысы булган Әхәт Гобәйдуллинны да өстәмә хөкемгә тарту өчен материаллар әзерләп озаттым һәм, әлбәттә, Вәкил Таҗиевның әнисенә хәбәр итәргә дә онытмадым.* К.Булатова. *Аннан, шартыннан чыгып, кулыннан килгән, булдыра алган ир-егеткә ул кадәр хөкемгә тарттырырлык җинаять тә түгелдер инде ул...* А.Хәлим. **Хөкем йөртү** 1) Уйлау, фикер йөртү. *Барый да Мөхәммәтнең ни әйтергә теләгәнен шундук төшенеп алды һәм, үзен гаепле сизгәндәй: – Үзебез турында без идеаллар аша, калган кешеләр хакында аларның гамәлләре буенча хөкем йөртәбез, – дип куйды.* З.Хөснияр. *Син үз авылыбыз каланчасыннан карап кына хөкем йөртмә, Мәгышия апа.* В.Нуруллин; 2) Хуҗа булып тору, идарә итү, җитәкчелек итү. *Тик ул сиңа хезмәт итсен иде, Синең өстән хөкем йөртмәсен!* К.Булатова. *Гаделсезләр хөкем йөрткән чакта, Халык арына алмый нужадан.* В.Галиев. **Хөкем сөрү** 1) *к.* **хөкем йөртү** (*2 мәгъ.*). *Тарихка, җырларга, дастаннарга кергән Бөек Болгар дәүләтендә бик күп ханнар хөкем сөргән.* Р.Батулла. *Россия, патша хөкем сөргәндә үк, чиновниклар иле булган.* Р.Миңнуллин; 2) Нәрсәнең дә булса өстенлек алуы, өстенлек итүе. *Робертның шигъри почмагында тыйнаклык, әдәплелек, ихтирамлылык хөкем сөрә, тәрәзәләрендә кояш уйный.* Н.Гамбәр. *Тирә-якта илаһи тынлык хөкем сөрә иде.* А.Әхмәтгалиева

**ХӨКЕМДАР** *и. гар.-фар.* 1) Берәр дәүләтнең башлыгы булган һәм хөкем итү, әмер итү хакы булган зат: падишаһ, кахан, император. *Патшаның вәзире боларны хөкемдар янына чакыра.* Ф.Урманче. *Ике урынлы тәхетнең бер ягында хөкемдар үзе, икенче ягында аның хатыны булып, җитди мәсьәләләрнең барысын бергәләп хәл иткәннәр.* Ф.Хуҗин

2) *юг.* Аллаһ, Ходай Тәгалә. *Ходай үзе хөкем итсен. Ул – хөкемдар.* Н.Каштанов. *Һәр ике як та үзенең хаклы булуына нык ышанган, әмма Мәрьямбану ягында хөкемдар – Аллаһы Тәгалә, укытучылар ягында – кеше фикере.* Ф.Бәйрәмова

3) *күч.* Билгеле бер вакытта, урында, тирәлектә эш-гамәлләре, сүзе, фикере һ.б.ш. белән иң мөһим, әһәмиятле булган кеше яки предмет. *Бу әле – Фәтхулла хәзрәтләрнең хөкемдар чоры.* М.Мәһдиев. *Әнә күктә бүтән «кошлар» – тимер очкычлар хөкемдар.* Н.Гыйматдинова

4) *күч.* Нәрсәне дә булса хәл итүче, урынына куючы, аңлаешлы итүче. *Кылган эш-гамәлләреңә Вакыт хөкемдар булса, сырхау-авыруларыңа иң зур, иң кодрәтле табиб – шулай ук Вакыт галиҗәнаплары.* Н.Әхмәдиев. *Вакыт кына хөкемдар бу дөньяда.* Х.Ибраһим

**ХӨКЕМДАРЛЫК** *и.* 1) Хөкемдар булу; хөкемдар вазифасы. *Хөкемдарлыкның мәгънәсен ул гавам мәнфәгатьләренә хезмәт итүдә күрә.* Х.Миңнегулов. *Күп алтын тәңкәләр күрсәң, хәзинә, хикмәт, хөкемдарлык, гөнаһлардан котылудыр, диләр.* Ф.Яхин

2) Хөкемдар кыяфәте, үзен тотышы, рәвеше. *Аның тавышыннан хөкемдарлык бөркелеп тора.* Р.Батулла

**ХӨКЕМДАРЛЫ́К ИТҮ** *ф.* Хөкемдар вазифаларын башкару; дәүләт белән идарә итү. *Син хөкемдарлык иткән, син яшәгән гарип дөньяны шундый адәмнәр үз кулларына алачак.* Ә.Баян. *Быел ул егерменче елын хөкемдарлык итә.* Т.Нәҗмиев

**ХӨКЕМДАРЛЫ́К КЫЛУ** *ф. к.* **хөкемдарлык итү**. *Ул кардәш төрек халкы төзегән, дөньяда гаделлек һәм иминлек сакчысы булган Бөек Госманлы дәүләтенең (Дәүләте гали Госмания, 1299–1923) иң шәүкәтле чорындагы падишаһы, 46 ел буе хөкемдарлык кылган шанлы Сөләйман солтан турында кыйсса язарга батырчылык иткән.* В.Имамов. *Ил белән идарә итү, димәк, хөкемдарлык кылу – тәкъдир хөкемен үз кулыңда тоту дигән сүз ул!* Ф.Яхин

**ХӨКЕМЕНДӘ** *бәйл.* Урынында, дәрәҗәсендә; кебек. *Ләкин карт алдында ул барыбер бала хөкемендә.* Г.Сабитов. *Мин хәзер сабый хөкемендә.* Д.Салихов

**ХӨКЕ́М ИТҮ** *ф.* 1) Уйлау, фикер йөртү, нәтиҗәгә килү. *Анысы турында укучым үзе хөкем итәр.* Р.Ягъфәров. *Тагын шунысы да бар: үз Казаныңда татарча чыккан китапны үз өеңдәчәрәк, үзең белгән таныш укучыларың белән бергәрәк торып һәм уртак югарылыктан чыгыбрак укыйсың, хөкем итәсең.* Р.Фәйзуллин

2) Кемгә (нәрсәгә) дә булса яки кемнең дә булса эшләренә, үз-үзен тотышына бәя бирү. *Сез үзегезгә карап хөкем итмәгез.* Р.Батулла

3) Нәрсә өчен дә булса гаепләү, битәрләү. *Мин хөкем итәргә уйламыйм, Бу хәлгә гаепле үзем дә.* И.Юзеев. *Гомумән, мин аны хөкем итә дә, ачулана да алмадым, бу дөньяда күп яшисе калмаган иде инде, ә иң мөһиме – аны мин хөрмәт итә, ярата идем.* Р.Мирхәйдәров

4) Кемнең дә булса кылган гамәлен, җинаятен суд тәртибендә тикшерү, карау. *Нәрсә өчен хөкем итәргә кирәк икән аны: кылган җинаяте өченме, әллә аңламаганы өченме?..* З.Хәким. *Намуслылык, тырышлык, гаделлек, тәрбиялелек, әдәплелек, төгәллек, миһербанлылык һәм башка бик күп сыйфатлар бу һөнәр ияләреннән аерылгысыз булса гына, бездә җинаятьчеләр дә кимер, ялгыш хөкем итүләргә дә чик куелыр, хәтта ки гаепләнүчеләргә дә кешечә караш яшәр.* Р.Рахман

5) Берәр җинаятьтә, эштә гаепле санап, законсыз гамәлдә хөкем карары чыгару, нинди дә булса җәза билгеләү. *– Сезнең дустыгыз, – диде ул, басым ясап, – җәмәгать урынында хулиганлык ясаган өчен биш елга хөкем ителде.* А.Гыйләҗев. *Моны Солтанъяр болай аңлады: үлемгә хөкем ителгәннәрне вак хулиганлык өчен җәзага тарттырып булмый бит инде.* З.Мурсиев

6) Өстенлек итү, хөкем сөрү. *Әле язлар төшкә генә керә, Хөкем итә кырлач салкыны...* М.Мирза. *Биредә ике төрле психология хөкем итә: руслар үзләрен бөтен ил хуҗасы дип исәпли, ә татарлар – үз авыллары хуҗалары дип.* М.Миначев

**ХӨКЕМНАМӘ** *и. гар.-фар.* Хөкем карары язылган кәгазь, карарнамә.

*Хөкемнамә белән танышу өчен вакыт бирелде*

**ХӨКҮМӘТ** *и. гар.* Илдәге дәүләт хакимиятенең иң югары коллегиаль башкарма органы. – *Әле генә корылтай Вакытлы хөкүмәт төзү турында карар чыгарды, – дип, ул соңгы хәбәрне җиткерде.* М.Әмирханов. *Матбугатта, халыкара әһәмияткә ия бу чарада катнашучыларны котлап, хөкүмәт җитәкчесенең рәхмәт хаты басылды.* М.Садыйков

**ХӨЛЛӘ** *и. гар.* 1) Чапанга охшаш җиңел өс киеме. – *Мөфти хәзрәттә дә юк мондый хөллә, – диде Шәйхи, телен шартлатып, – Мәккә-Мәдинәләрдә дә ушлары китәр иде.* М.Әмирханов. *Сәләмә хөллә кигән, башларына яулык чорнаган гарәпләр куй көтүләрен чатырларына таба акрын гына куалар.* М.Мәһдиев

2) *күч.* Гомумән кием. *Аллаһы Тәгалә --- явызлыкларын гамәл дәфтәрләренең эчке ягына, яхшылыкларын тышкы ягына куяр, башына энҗеләр-җәүһәрләр белән эшләнгән алтын таҗ киертелер һәм җитмеш хөллә (кием) киярләр, кулларына алтыннан-көмештән-энҗедән беләзек киертелер.* Ф.Яхин. *Хөллә – сырып тегелгән җиңел өс киеме.* Безнең мирас

3) *күч.* Нәрсәне дә булса каплап алган, өстен япкан әйбер. *Агачлар үзләренең куе ботаклары, яшел хөлләләре белән безнең дүрт ягыбызны да чолгап алдылар.* Ф.Әмирхан. *Җил артыннан зәңгәр дулкын ага – Килер язның батист хөлләсе!* С.Гәрәева

**ХӨР** *с. гар.* **1.** 1) Ирекле, бәйсез, азат. *Кош шикелле хөр ул Шигырь, Болыттай ак болай да.* Г.Морат. *Кол гына күрәшә. Хөр кеше көрәшми.* З.Хәким

2) Борчусыз, хафасыз. *Шулай икенче төрле – хөр, сәгадәтле тормыш башланды.* М.Мәһдиев. *Тамак туйдырып, хөр күңел белән, аяк киемнәрен салып куеп урын өстенә сузылырга уйлаган иде, итегендә балта эзе күреп аһ итте.* К.Кара

3) Ирекле, бәйсез (фикер, дөньяга караш тур.). *Кызымның хөр фикерле булуын, үзен җирдә иркен сизүен телим.* А.Гыйләҗев. *Илле шәкерт белем ала торган зур булмаган мәдрәсә аның тырышлыгы белән тиздән дан-шөһрәт казана, аңа хөр фикергә сусаган яшьләр тартыла, алдынгы карашлы мөгаллимнәр килә.* Г.Мөхәмматшин

**2.** *рәв. мәгъ.* Ирекле, бәйсез рәвештә, азат булып. *Кеше бит ул читлек кошы түгел, Хөр яшисе килү кемгә ят?* Н.Әхмәдиев. *Берүк озын гомерле бул, азат һәм хөр яшә, газиз Казан калам!* В.Имамов

**3.** *и. мәгъ.* Ирекле, азат кеше; кол булмаган кеше. *Хөрләрнең хокукын бозу*

**ХӨРӘСӘН** *и. фар. сөйл. кимс.* **1.** 1) Эшлексез, ата ялкау кеше, әрәмтамак. *Минем баҗамнан да – шушы хөрәсәннән дә җүнлерәк кияү табалмадыңмы, ахмак кыз?* И.Юзеев. *Берзаман хатын уята: – Тор, хөрәсән, син бит Әхмәткә концерт куярга барырга вәгъдә иткән идең.* А.Хәмзин

2) *күч. сөйл.* Зәхмәт, явыз, яман нәрсә; хәшәрәт. *Авылга грипп дигән хөрәсән керде бит.* Д.Салихов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Ялкау, әрәмтамак, эшлексез, үшән. *Үз гаебен аңлый алмаган Әмир әүвәл өендә, нигездә хәл белгән булып, бушлай баш төзәтү хыялы белән йөргән ялкау, хөрәсән ир-ат даирәсендә буталды, аннан үзен кулга алып, университетка керү имтиханнарына әзерләнә башлады ---.* Т.Галиуллин. *Әллә симерүдән тиреңә сыеша алмый башладыңмы, хөрәсән җан?!* В.Имамов

2) Көчсез, егәрсез, мескен, хәлсез. *Күңеле йоклаган адәмнәр, Хөрәсән йөрәкләр юк түгел.* Ш.Галиев

◊ **Хөрәсән ялкавы** Үтә ялкау, әрәмтамак, эшлексез кеше. *Ындырга барабыз шулай, авылыбызның хөрәсән ялкавы Мөхтәр абзыйны очраттык.* Р.Батулла. *Үзенә генә түгел, күршекүләннәр Дилемманың хәтта әтиәнисенә кереп әйттеләр: кызыгызның буе бар, төсе бар, нишләп шул хөрәсән ялкавына бәйләнгән, гармун ашап яшәрләрме әллә, диделәр.* З.Мурсиев

**ХӨРӘСӘНЛӘНҮ** *ф. сөйл.* Ялкаулану, эшлексезләнү, ялкауга әйләнү. *Хәзер төп мәшәкать аларда, ирләр, хөрәсәнләнеп, гаилә кайгыртуны да тулаем аларга тапшырдылар.* Ш.Галиев. --- *гаилә кору яшенә җиткәндә үк, кыз бала инде карьера ясаган, матди киләчәген кайгырткан, егетләр исә, хөрәсәнләнеп, эш тапмыйча йөри.* Ватаным Татарстан

**Хөрәсәнләнә башлау** Хөрәсәнләнергә тотыну. *Хөрәсәнләнә башлавымны үзем дә сизәм инде.* Кызыл таң

**Хөрәсәнләнеп бетү** Тәмам хөрәсәнләнү. *Яшьләр хөрәсәнләнеп бетте*

**Хөрәсәнләнеп тору** Озак вакыт дәвамында хөрәсәнләнү

**Хөрәсәнләнеп яту** *сөйл. к.* **хөрәсәнләнеп тору**. *Малай, җитәр сиңа бакча тирәсендә хөрәсәнләнеп ятырга!* Т.Нәбиуллин

**ХӨРДӘЛӘ́Ү** *ф. диал.* Алдау, хәйләләү. *Аяк чалып, хөрдәләп җиңсәң генә.* А.Гыйләҗев. *Тәмле тел белән чакырып чыгардылар да тегеләрне, егерме бишәр доллар белән хөрдәләп, ярты сәгать чамасы йөреп кайтырга куштылар.* Ф.Баттал

**ХӨРЛЕК** *и.* Ирек, азатлык. *Хөрлеккә, азатлыкка, үткән бөеклекне аңлауга зур бер адым иде ул.* Б.Рәхимова. *Бабаларым иркен дала буйлап Ил хөрлеге даулап йөргәндер.* И.Гыйләҗев

**ХӨРМӘ** *и. фар.* 1) *бот.* Пальмачалар семьялыгыннан борынгы чорлардан ук Төньяк Африкада культуралаштырылган, озын кәүсәле, зур яфраклы көньяк агачы; хөрмә агачы, хөрмә пальмасы. *Пәйгамбәр галәйһиссәламнең кулында бер хөрмә ботагы бар иде.* К.Насыйри. *Урамнарда, таштан салган зуррак йортларның ихаталарында сәрви, алмә, зәйтүн, хөрмә куаклары күкрәп утыра, арада керпе сыман бөгәрләнгән күгән-сырганаклар, борыннарын күккә сузган, каурыйларга охшаган карагайлар, кипарислар да күп.* В.Имамов

2) Шул агачның ашарга яраклы, көрән төстәге татлы һәм туклыклы, күбесенчә киптерелгән килеш кулланыла торган җимеше; *русчасы:* **финик**. *Кайтып кереп, өстәл өстенә капланган газетаны ачып җибәргәч, андагы лимон-мандариннарны, хөрмә-виноградларны, кавын һәм карбызны күреп, Розаның күзләре шар булды.* В.Нуруллин. *Галим бабай да, Айдар белән Хәйдәр дә, бисмилла әйтеп, хөрмә, йөзем ише җимешләрне, төрле тәм-томнарны җиңелчә генә авыз итеп алдылар да, «Аллаһу әкбәр!» дип, урыннарыннан кузгалдылар.* Л.Лерон

3) *сөйл.* Шул җимешнең тәсбих ясау өчен кулланыла торган озынча каты төше. – *Кызу чапсагыз, тиз барып җитәрсез! – ди ишан шактый дорфа итеп һәм, ашыгып, тәсбихенең «хөрмәләрен» тарта башлый.* Ә.Еники

4) *бот.* Эбенчалар семьялыгыннан татлы җимеш бирә торган көньяк агачы яки куагы. *Хөрмә бакчасы*

5) Шул агачның яки куакның кызгылт сары төстәге татлы җимеше; *русчасы:* **хурма**. *Салкын килеш тәмле ул хөрмә. Әй, кыш булса, өшетеп ашар идең. Ай тәмле дә була соң өшегән хөрмә!* Р.Бәшәр. – *Бу хөрмәләр өлгереп җитмәгән әле, авызны бөрештерә, әнә тегеләрен алыгыз, – диде ул елмаеп.* Сөембикә

◊ **Хөрмә кебек** Бик матур, чибәр, гүзәл. *Минә икенче кызы да, пешеп*

*җиткән хөрмә кебек, өзелеп төшәргә генә тора.* Т.Галиуллин. *Хөрмә кебек чибәрләрнең Урыны була түрдә.* Р.Вәлиев

**ХӨРМӘТ** *и. гар.* Ихтирам; олылау, зурлау. *Моннан ары әбекәй янынннан хөрмәт белән баш иеп узачакмын мин.* А.Мансуров. *Ә халык хөрмәтен, халык рәхмәтен казанудан да зуррак тагын нәрсә бар бу дөньяда?..* В.Нуруллин

**ХӨРМӘТЕНӘ** *бәйл.* 1) Өчен, хакына. *Бүген исә, күтеп алган кунак хөрмәтенә, эштән иртәрәк кайтканнар, мич торбаларыннан төтен чыгып тора.* Р.Мөхәммәдиев. *Соң, апа, бүген Гүзәлия хөрмәтенә табын көйләргә иде бит.* Н.Гыйматдинова

2) Уңае белән, багышлап; уңаеннан, уңаенда. *Ә бәлки, бу – чынлап та туган көн хөрмәтенә җибәрелгән күчтәнәчтер, ә?* Ф.Яруллин. *Бәлеш пешү хөрмәтенә Табагач та кузгала: Кызу мичтән, эләктереп, Кайнар бәлешне ала.* С.Әхмәтҗанова

**ХӨРМӘ́Т ИТҮ** *ф.* 1) Олылау, ихтирам итү, зурлау, ярату, тану, санлау. *Карасуда, Нәбиулла туган, сине беләләр, хөрмәт итәләр.* Т.Галиуллин. *Ул бик әйбәт кеше иде, мине яратты да, хөрмәт тә итте.* А.Әхмәтгалиева

2) Кунак итү, кунакчыллык күрсәтү. *Соңгы баруында Мирхәйдәр абзый аны, хөрмәт итәсе килеп, «әче су» белән сыйлап җибәрде.* Ә.Фәйзи. *Ул карчык хатын боларга хөрмәт итеп, бер палас китереп җәйде, утырдылар.* М.Гайнетдин

3) Тәрбияләү, тәрбия күрсәтү, ярдәм итү, кадер-хөрмәт күрсәтү. *Әтисен шулай хөрмәт итүе өчен, хатыны аңа әле дә рәхмәтләр укый, ди.* Әкият. *Ике инәйләрен дә бертигез яратып хөрмәт иткәннәр.* З.Зәйнуллин

**ХӨРМӘТЛӘ́Ү** *ф.* 1) Олылау, зурлау, ихтирам итү, санлау. *Тирә-ягыма карадым, ләкин мин хөрмәтләгән оста күренмәде.* М.Хуҗин. *Үз баласын юньләп багып тәрбия итә алмаган кеше ничек итеп бүтәннәр баласын сөя алсын, үз милләт-кавемен кадерли белмәгән адәм ничек башка халыкларны хөрмәтли алсын!* Р.Фәйзуллин // Кунакчыллык, игътибар күрсәтү. *Доцент Захаров урыныннан торып, хөрмәтләп каршы алды.* А.Гыйләҗев

2) Төрле әйберләрне, материаль байлыкларны кадерләү, саклап тоту, аларга сакчыл мөнәсәбәттә булу, кадерен белү. *Ул үз көче белән эшләп тапкан тәгамны хөрмәтли, әрәм-шәрәм итми, чүплеккә ыргытмый.* Р.Батулла. *Мөнирә апагыз ул килешүне, йөз мең сум акчаны хөрмәтләгән кебек итеп, кием шкафындагы шүрлеккә пөхтәләп яшереп куйды.* К.Кәримов

3) Тәрбияләү, тәрбия күрсәтү, карау, багу. *Балага ни күрсәтеп, нинди тәрбия биреп үстерәсең, картлыкта ул сине шулай итеп я хөрмәтләр, я типке көнендә йөртер.* Сөембикә. *Анам да юк, атам да юк, Гыйльфан, син дә ташлап киттең, Мине кемнәр хөрмәтләр?* Милли-мәдәни мирасыбыз

**Хөрмәтләп бетерү** Барысын да хөрмәтләү, тиешле дәрәҗәдә хөрмәтләү, бик нык хөрмәтләү. *Кадерен белеп, хөрмәтләп бетерә алмадык кебек без аны.* Татарстан яшьләре

**Хөрмәтләп килү** Күптәннән һәм даими рәвештә хөрмәтләү. *Аны ничә еллар буе олылап, хөрмәтләп килделәр дә, менә хәзер авылдан ук ку, имеш!* Г.Әдһәмова

**Хөрмәтләп тору** Гел, һәрвакыт хөрмәтләү. *Алкышларыбыз белән гел хөрмәтләп торабыз үзләрен, җаныбызга рухи азык бирүләре өчен рәхмәт яудырабыз.* Р.Юсупова. *«Тормышымнан канәгатьмен, чөнки намуслы хезмәтемнең җимешләрен күрү, укучыларымның мине хөрмәтләп торулары миңа яшәргә көч бирә, картаймаска этәрә», – дип елмаеп озатып калды ул мине.* Шәһри Казан

**Хөрмәтли башлау** Хөрмәтләргә тотыну. *21 яше тулганда Мәккә җәмәгасендә Мөхәммәдне, ышанычлы һәм турылыклы кеше буларак, Әмин дип хөрмәтли башлыйлар.* А.Тимергалин. *Кайчан безне тыл ветераннары белән бер дәрәҗәдә хөрмәтли башларлар икән?* М.Мәгъсүмов

**ХӨРМӘТЛЕ** *с.* 1) Хөрмәткә, ихтирамга лаек булган, хөрмәт ителә торган. *Безнең өчен Сибгат ага Хәкимнең хатыны – хөрмәтле Мөршидә апа үрнәк булды.* Ш.Галиев. – *Атаң-анаң бик хөрмәтле кешеләр иде, балам, – диде ул, алдан сукмак буйлап барганда. – Сине дә бер кайтырсың дип көткән идек.* Х.Ширмән

2) Мөрәҗәгать итү сүзе алдыннан: хөрмәткә лаеклы. *Нигъмәтулла абзыкай тәпәннең өстен ачты, чүмеч белән бер шөбердәтеп коеп карады, аннары кунакларга карап әйтте: – Хөрмәтле кодалар, туебызның иң зур сые – кыз балы табынга килде.* Ә.Еники. *Калай савытка бәрелеп чыңлаган кашык тавышы, чапылдатып чәйнәгән авазлар тына төшкәч, Рәфис сүз алды: – Хөрмәтле иптәшләр! – диде ул, барысына да ишетелсен өчен тавышын күтәрә төшеп. – Әйбәт эшләдегез, рәхмәт сезгә!* А.Вергазов

3) Кемгә яки нәрсәгә карата хөрмәт хисе белән карый торган, күңелендә хөрмәт хисе саклый торган; хөрмәт итеп яши торган; ихтирамлы, шәфкатьле, игътибарлы, ярдәмчел. *Мин сиңа гомерем буе хөрмәтле булыр идем.* Ф.Баттал. *Хәер, ул теле белән дә әйтте: – Сәрия апаңа хөрмәтле бул.* Р.Габделхакова

4) Хөрмәт итеп, ихтирам белән әйтелә торган мөрәҗәгать сүзе. *Син, хөрмәтлем, алай тәмам бирешмә инде.* А.Хәсәнов. *Әй хөрмәтлем! Җәмилкәем! Нәрсә дә булса уйлап тап.* Д.Салихов

**ХӨРМӘТСЕЗ** *с.* **1.** 1) Хөрмәттән мәхрүм, кадерсез, ихтирамсыз. *Хөрмәтсез кешеләр*

2) Хөрмәт итмәүне белдерә торган. *Мөгаен, үзенең шәхесенә карата мондый саксыз, хөрмәтсез карашны көтмәгән булгандыр.* Ф.Яхин. *Үзебезнең күпчелек хастаханәләрдәге чиратлар, этеш-төртеш, табиб белән пациент арасындагы хөрмәтсез мөнәсәбәт, табибларның һәрчак талчыккан, кырыс чырайларына ияләшкәнгә, андагы хастаханәләрдәге тәртип, авыру артыннан тәрбия кылу дәрәҗәсе шаккатырды.* А.Галимов

3) Кадерләнми торган, ташландык хәлдәге (әйбер тур.). *Хөрмәтсез әйберләнең гомере кыска.* Әйтем

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Кадер-хөрмәт, рәхимшәфкать, тәрбия күрмичә. *Революция тәмам җиңгәннән соң, Вәли бай да, иленә кайтып, кадерсез, хөрмәтсез яши башлый.* Г.Нигъмәти

2) Хөрмәт итмичә, кадерен белмичә, санламыйча. *Чөнки бу – милләтебезнең гасырлар буена килгән гадәтен, йоласын белмәү, аңа хөрмәтсез карау булыр иде.* Р.Батулла

**ХӨРМӘТСЕЗЛӘ́Ү** *ф.* Хөрмәтсезлек күрсәтү, кимсетү, үпкәләтү. *Әмма Сабираның хөрмәтсезләп әйткән кебек чыккан сүзләре аның бәгырен кисеп алгандай хәсрәтле иттеләр.* Ф.Яхин. *Алар моны ил җитәкчесен хөрмәтсезләү дип кабул иткән.* Р.Харрасова

**ХӨРМӘТСЕЗЛЕК** *и.* Хөрмәт булмау, хөрмәт итмәү, санашмау билгесе; берәр кешегә карата игътибарсыз булу. *Туган ил өчен шәһид киткән изге җаннарга хөрмәтсезлек була түгелме соң бу, иптәшләр?!* Х.Сарьян. *Минемчә,*

*үз милли бәйрәмеңдә, үз халкың алдында чит кавем телендә чыгыш ясау – үз-үзеңә, милләтеңә, халкыңа хөрмәтсезлек билгесе.* Безнең мирас

**ХӨРРИЯТ** *и. гар.* Хөрлек, азатлык, ирек, бәйсезлек. *Бу сугышта кулларына корал тотып катнашкан, бөтен халык өчен хөррият, ирек яулашкан батыр йөрәкле якташларыбыз исеме безнең көннәрдә һич онытылмыйча сакланырга тиеш.* Л.Хәмидуллин. *Тик шул чакта гына безнең татар халкы бүтән халыклар белән тигез хокуклы булыр, тик шул чакта гына безнең халкыбыз хөрриятка һәм якты көн күрә башлауга ирешер!* В.Нуруллин

**ХӨРТ** *хәб. сөйл. к.* **хөрти**. *– Хәлләр бик тә хөрт, – ди танавын салындырган, иренен сәлендергән Көнчел.* А.Хәлим. *Эше хөрт бүтәннәрнең дә: Өргәк этләр өрми бер дә. Тешләми дә, ди, ул этләр...* Р.Миңнуллин

**ХӨРТИ** *хәб. сөйл.* **1.** Начар, шәп түгел, яман, рәтсез. *Читтән караганда да үзгәреш сизелгәндер, Гайнулла аңа текәлеп башын чайкады: – Эшләр хөрти синең, салкын суккан, ахрысы.* К.Кара. *Хәлләр хөрти бит, кызый.* Н.Гыйматдинова

**2.** *с. мәгъ.* Начар, хәчтерүш, сәләмә. *Бу кулдан гына ясалган, буялмаган, хөрти генә бер скрипка иде.* Ә.Еники. *Болай да хөрти киемен умыру егетлек түгел, дим.* Х.Камалов

**ХӨРТИЛӘНҮ** *ф. сөйл.* Начарлану, шәп булмау, яманга әйләнү, рәтсезләнү, рәте китү. *Җәйләр, көзләр үтеп, кышка кергәч, хәлләре хөртиләнде Ханәфинең.* В.Нуруллин. *Керемне саныйсың, чыгымны чутлыйсың, эшләр хөртиләнгән кебек булса – янасың-көясең, аз-маз табыштан да башың күккә тия, дөньяның бар рәхәте шулдыр кебек тоела.* Ф.Сафин

**Хөртиләнә бару** Торган саен ныграк хөртиләнү. *Мәктәптә эшләр көннән-көн хөртиләнә барган һәм бер заманны бөтенләй чыгырдан чыккан.* Р.Вәлиев. *Әсмабану абыстайның хәле хөртиләнә бара: телдән бик зарланмаса да, ничектер авыр сулый.* С.Сабиров

**Хөртиләнә башлау** Хөртиләнүгә табан үзгәрү. *Югыйсә эшләрем көннән-көн хөртиләнә башлаган иде.* И.Салахов. *Эшнең хөртиләнә башлавын иң әүвәл җитәкчеләребез авызыннан «субъект» дигән сүз чыккач сиздем.* Р.Вәлиев

**Хөртиләнә төшү** Бераз гына хөртиләнү; тагын да ныграк хөртиләнү. *Ул вакытта эшләр дә хөртиләнә төшкән иде бит.* И.Нуруллин

**Хөртиләнеп китү** Соңгы арада бераз хөртиләнү; кинәт хөртиләнү. *Хуҗа, бу бай хатын ниндидер мәкер белән бурычка акча сорарга килгән, дип уйлап, кунакның күңелен рәнҗетмәскә тырышып, иплән кенә, хәленең хөртиләнеп китүен аңлатырга тырышты.* Т.Галиуллин. *Аның унбиш минутка сузылган нотыгыннан шул аңлашылды: безнең оешманың эшләре таудан түбән тәгәри башлап, хөртиләнеп киткән икән.* Шәһри Казан

**Хөртиләнеп тору** Әле, хәзерге вакытта хөрти булу; вакытлыча хөртиләнү. *– Хәлләр хөртиләнеп тора әле, – диде Гаяз боек тавыш белән.* Мәйдан

**ХӨСЕН** *и. гар. иск.* Матурлык, күркәмлек, гүзәллек. *Белми инсан: дөньяда кайсы хөсен, кайсы яман.* Г.Тукай. *--- бер кабернең янында – бер хатын, нурлы йөзе тулымнары эчендә болыт арасыннан күренгән кояш кебек балкып торыр; хөсен вә җәмал иясе бер хатын аһ-ваһ итеп егълар.* К.Насыйри

**ХӨСЕТ** *и. гар.* **1.** 1) Көнчелек; көнләшү, яратып бетермәү аркасында башкаларга карата булган начар уйлар, мөнәсәбәт. *Ант итегез, оланнарым, сез дә: арагызга дошман кертмәскә, күңелегездә хөсет йөртмәскә, сугышмаска, орышмаска, тату булырга!* Р.Батулла. *Теләсәң, үс, ирек иде, Берсендә дә юк хөсет.* Н.Сафина

2) *ялг. к.* **хасид**. *Әмма эчләре янып йөргән әлеге хөсетләр өчен бу хәлләр күктән көткәнне җирдән табу белән тиң иде.* М.Госманов

**2.** *с. мәгъ. к.* **хөсетле**. *Мотаһирны Мәскәүдәге олы җитәкчеләр кушуы буенча түгел, ә шул ук авылда яшәп яткан бер хөсет адәм «чакканга» күрә алалар.* М.Хәсәнов. *Шапшак, хөсет, гайбәтче, кеше сөймәс хатыннарның тәрәзәләре дә аларның чытык йөзләре кебек була, мәңге ачылмаслар.* И.Нәбиуллина

**ХӨСЕ́Т ИТҮ** *ф. к.* **хөсетләнү**. *Мәгәр падишаһ тирәсендә ярамас һәм бозык кешеләр бар, шулар минем мәртәбәмә хөсет итеп, көнләшеп чаккан булырлар һәм, минем хаклыгым, гаделлегем аларның яманлыкларына киртә булган өчен, миңа төрле ялалар ябып, хыянәтче итеп күрсәткән булырлар.* Кәлилә вә Димнә. *Кеше бәхетенә хөсет итмәде.* М.Фәйзи

**ХӨСЕТЛӘНҮ** *ф.* Көнләү, көнләшү, кеше әйберен, кеше уңышын күпсенү. *Ахыр чиктә: «Шулай инде... Үзләренең кулыннан килмәгәч хөсетләнәләр...» – дип, үз-үзен тынычландырырга тырышты.* М.Хәсәнов. *Әмма Шәрифулла агай әтигә хөсетләнүен барыбер туктатмый, тәки әтине председательлектән төшерттерә.* В.Нуруллин

**Хөсетләнә бару** Торган саен ныграк хөсетләнү. *Кыз вакыт үткән саен хөсетләнә бара*

**Хөсетләнә башлау** Хөсетләнергә тотыну. *Аннан, матур, дөрес итеп, тәртипле булып, үрнәк күрсәтеп яшәгән кешене күреп, кемнеңдер эче поша, хөсетләнә башлый.* Акчарлак

**Хөсетләнә төшү** Беркадәр, бераз хөсетләнү; тагын да ныграк хөсетләнү

**Хөсетләнеп йөрү** Даими, һәрвакыт хөсетләнү. *Беркемгә зыян салганым, хөсетләнеп йөргәнем, әшәкелек эшләү хакында уйлап та караганым юк.* Шәһри Казан

**ХӨСЕТЛЕ** *с.* Башкалар уңышына, байлыгына һ.б. куана алмый торган; бүтәннәрнең яхшы яшәвен авыр кабул итә торган; көнләшүчән. *Байлыкка табынып яшәүче, хөсетле һәм эчкерле кешеләр бер кул белән генә көрешергә тырышыр – икенче кулын кесәсеннән чыгармас.* К.Кәримов. *Үзен шулай шактый һавалы тотса да, бер дә нәфесле һәм хөсетле түгел: эшләгән эше өчен хезмәт хакын беркайчан да үзе куймый, кем ни китерсә – шуңа, кем күпме китерсә – шуңа канәгать.* В.Нуруллин

**ХӨСЕТЛЕК** *и.* Көнчелек. *Колагың ишетсен: бу эшне хөсетлек белән уйлап, миңа, миннән бигрәк киленгә сүз ишеттерерлек булсаң, каргап, каргадан күзеңне чукытырмын.* А.Гыйләҗев. *Яманлыгы, хөсетлеге ташып чыкса, сине пычратып ташларга да тартынмас.* Г.Хөсәенов

**ХӨСНЕЗАН** *и. гар. иск.* Кемгә дә булса уңай караш, яхшы уй, яхшы фикер. *Бәлки, Габдулла үзе дә хисап биреп бетермәгән, һәрхәлдә, телдән әйтү ихтималы булмаган икенче сәбәп – шикләнү, сагаю, үзенең «мин»е, хөснезаны өчен хәвефләнү булырга мөмкин.* И.Нуруллин. *Ялганламасаң, аларның хөснезаннарын (яхшы уйда булуларын) бозу була иде.* М.Хәсәнов

**ХӨСНЕЗА́Н ИТҮ** *ф. иск.* Яхшы уйда, фикердә булу. *Әстерханы, --- Төркестаны, Кавказы, әлбәттә, шул мәсьәләдәге бурычын үти торгандыр. Без шулай хөснезан итәбез.* Г.Исхакый

**ХӨСНЕЗА́Н КЫЛУ** *ф. к.* **хөснезан итү**. --- *берәү сине изге кешедер дип хөснезан кылса, аңа хыянәт белән ярамас эш кыйлып, аның хөснезанын бозма.* К.Насыйри. *Очраган бер кешегә хөснезан кылу вә кем туры килсә шуңардан алдану яхшы эш булмаган кебек, һәркемгә сүизан кылу да яхшы эш түгеллеген Ризаэтдин бине Фәхретдин бик ачык әйтә.* А.Тимергалин

**ХӨСНЕНИЯТ** *и. гар. иск.* Яшерен начарлыгы булмаган, күркәм, яхшы ният. *Ходайдан куркыр идең, морза, атаң кебек кеше ләбаса мин, Коръән Кәрим өлкән яшьтәге тәкъва адәмнәрне хөрмәт итәргә куша, хөсненият белән яшәү фарыз, догалыкларга ешрак күз салырга кирәк...* М.Әмирханов

**ХӨСНЕХАТ** *и. гар.* Каллиграфия, матур язу осталыгы. *Болардан тыш, Хөсәен бабаның хөснехат сәнгате, ягъни матур язу осталыгына ия булганлыгы да, үз гомерендә берничә йөз Коръән күчереп язганлыгы да Каюм Насыйриның истәлекләрендә хәбәр ителә.* Ә.Хәйри. *Төрекләрнең бөек архитекторы Синан (1480–1578) хөснехат осталарының хезмәтен бик югары бәяләгән һәм каллиграфия сәнгатен үзенен мигъмарчылык эше һәм осталыгы белән чагыштырганда югарырак дәрәҗәгә куйган.* В.Усманов

**ХӨТБӘ** *и. гар.* 1) Җомга, бәйрәм намазларында, никах вакытында гадәттә гарәпчә укыла торган дога, үгет. *Касыйм үзенә җомга намазында хөтбә укырга чират җиткәч кенә күңелендәге уйларын-хисләрен берьюлы ачып салды.* В.Имамов. *Бу шаһитлардан тыш, никах мәҗлесендә ир ягыннан бер вәкил, кыз ягыннан атасы яки яшькә олырак ир туганы һәм дә никах хөтбәсен укучының булуы шарт.* Ф.Яхин

2) Вәгазь; үгет-нәсыйхәт. *Җомга намазы сәеднең хөтбәсеннән башланды, ул да, Коръән аятьләренә нигезләп, илгә иманлы хуҗа кирәклеге турында сөйләде, вәлилекнең Аллаһтан булуын һәм аларга буйсынырга кирәклеген искәртеп үтте.* Ф.Бәйрәмова. *Һәр хөтбәсендә илнең бәйсезлеген якларга чакырган.* Р.Зәйдулла

**ХРАМ** *и. слав.* 1) *дини* Гыйбадәтханә. *Тора монда тугыз башлы храм – Мин, дигәндәй, җиңү патшасы.* Н.Нәҗми. *Нәкъ 11 тулганда, храмны коточкыч бер тавыш басты: кычкырган кеше ике кулына бер муенса күтәрде дә аңа тезелгән шөлдерләрне зеңгелдәтә башлады ---.* М.Мәһдиев

2) *күч.* Бик нык хөрмәт ителә, югары хисләр тудыра торган урын; бик кадерле, изге, бөек итеп кабул ителә торган йорт. *Шуннан соң ул озак еллар Чаллыда культура бүлеген җитәкләде, аннан соң, ниһаять, сәнгатебезнең иң олы храмы – Татар дәүләт академия театрының директоры булды.* Р.Батулла. --- *«Без – Казаннан, Без – Гыйлем-йорттан!» дип барча кыйтгаларга аваз салырлык камил белемле, зыялы милли шәкертләр әзерләүче остазны һәм, ниһаять, тәүге милли белем храмы – Татар университетын төзү кебек тарихи мәшәкатьләр белән мәшгуль шәхесне борчыйсым, аның кадерле вакытын билисем килмәде.* Р.Йосыпова

**ХРЕСТОМА́ТИЯ** *и. гр.* Әдәби әсәр үрнәкләре, аерым авторларның әсәрләре яки әсәрләреннән өзекләр китерелгән уку китабы. *Белем дәрәҗәләре дә, яшьләре дә төрле булган укучыларга яраклы хрестоматия төзү – авыр эш, әлбәттә.* М.Мәһдиев. *Хрестоматиядә бу шагыйрьләрнең биографиясе турында да мәгълүмат бар.* М.Хәсәнов

**ХРИЗАНТЕ́МА** *и. гр. бот.* Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан төрле матур төстәге катмарлы чәчәк ата торган декоратив үсемлек. *Шулай да ул балачактан ук китаплардан гына укып белгән серле зәйтүн, ташимән, хөрмә, айва, кузы чикләвеге агачларын, хризантема һәм олеандр гөлләрен таный.* Г.Рәхим. *Әмма Мөнир бүләк иткән хризантемаларны ул гомергә сакларга теләгәндәй, аларны кочагына кочып, бик сак атлады.* А.Хәсәнов

**ХРИЗОБЕРИЛЛ** *и. гр. махс.* **1.** Алтын сары яки яшел төстәге үтәкүренмәле асылташ. *Зөбәрҗәт, аквамарин, энҗе, ай ташы, хризоберилл, оникс кебек затлы ташларны ярата ул.* Сөембикә

**2.** *с. мәгъ.* Шул таштан ясалган. *Хризоберилл беләзек*

**ХРИЗОЛИТ** *и. гр. махс.* **1.** 1) Ачык яшел яки куе яшел төстәге үтәкүренмәле асылташларның гомуми исеме. *Ташлары: топаз, хризолит, фирүзә, сапфир, зөбәрҗәт.* Матур буласың килсә. *Алай гына да түгел, үзенең иҗат җимеше булган, хризолит ташыннан ясалган муенсаны, «Коллегама бүләк!» дип, мәктәбебезнең рәсем укытучысы Әлфия Бадыйкшанованың муенына үз кулы белән элде.* Заман сулышы

2) Шул таштан ясалган бизәнү әйберләре. *Бу йолдызлык астында туучыларга гәрәбә, хризолит, оливин, топаз тагарга киңәш ителә.* Безнең гәҗит

**2.** *с. мәгъ.* Шул таштан ясалган. *Хризолит муенса*

**ХРИСТИАН** *и. гр.* Христиан динендәге кеше, христианлык динен тотучы; христиан динен кабул иткән кеше. *Бүген – христианнар көне, Гайсә пәйгамбәр туган көн.* М.Хәбибуллин. *Мөселман кеше христианга һәм яһүдигә хөрмәт белән, әмма ялгыш юлга борылган динне тотулары өчен кызганып карарга тиеш.* Ф.Яхин

**ХРИСТИАНЛАШТЫРУ** *ф.* Башка дин тоткан халыкны христиан диненә тарту, күчерү; христиан итү. *Кайчандыр Иван Грозный мөселманнарны, явызлык кылып, христианлаштырган бит.* Л.Закир. *Русия елъязмачылары Святовитны үз тарихларына, христианлаштырып, Святослав дип язалар.* М.Хәбибуллин

**Христианлаштыра башлау** Христианлаштырырга керешү. *Бөекбритания Гавайны үзенең колониясе дип игълан итә һәм үзе кыргый дип бәяләгән халкын христианлаштыра башлый.* Сөембикә

**Христианлаштырып бетерү** Барысын да христианлаштыру, христианлаштыруны төгәлләү

**Христианлаштырып килү** Әкренләп христианлаштыру; күптәннән христианлаштыру белән шөгыльләнү

**ХРИСТИАНЛАШУ** *ф.* Христиан динен кабул итү, христиан диненә күчү. *Славяннар алданрак христианлашкан!* Т.Әйди. *Кызганычка каршы, керәшеннәрнең христианлашу тарихы фәндә ныклап өйрәнелмәгән, бу мәсьәләгә багышланган махсус хезмәтләр бик аз.* Н.Максимов

**Христианлаша бару** Торган саен ныграк христианлашу. *Ул, үзе дә сизмичә, елдан-елга руслаша, христианлаша бара иде.* Кызыл таң

**Христианлашып бетү** Тәмам христианлашу. *Әмма әби-бабаларыбызның аңлатып бетермәслек горур милләтпәрвәрлекләре һәм үҗәтлекләре аркасында, руслашып, христианлашып бетмичә, шушы көнгә кадәр татар булып килеп җиткәнбез.* М.Госманов

**ХРИСТИАНЛЫК** *и.* Безнең эраның беренче гасырында Рим империясенең көнчыгыш провинцияләрендә барлыкка килеп, Гайсә пәйгамбәргә табынырга өнди торган, чыганагы Изге Язма (Библия) булган дин (XI–XVI йөзләрдә

православие, католицизм һәм протестантлыкка бүленгән). *Белеклеге белән масайган егет рус миссионерлары белән тиз аралашып китә һәм алар тәэсирендә христианлыкны кабул итә – Александр Казембекка әйләнә.* Г.Гомәр. *Я хәзер үк чукынасың да христианлыкка күчәсең, я корабтан төшеп тә тормыйча кире борылабыз!* В.Имамов

**ХРОМ** *и. гр.* **1.** 1) *хим.* Аксыл соры төстәге көмешсыман ялтыравыклы металл, химик элемент. *Хром, марганец, бакыр, кургашын, цинк мәгъдәннәре, мәрмәр, ташкүмер һәм бүтән чимал чыганаклары инде күптән үзләштерелгән, алардан чыгарылган хәзинәнең бер өлеше байтактан бирле чит илләргә дә сатыла.* Т.Әйди. *Хромтау – дөньядагы иң эре хром рудасы табу урыны.* Р.Гыйлемханов

2) Шул металл тозлары белән иләп ясалган юка йомшак күн. --- *бакчада, иләнгән кәҗә тиресенең хромына төреп (Кукмара районы Ядегәрдә иләтеп кайткан тире), сигез мең акча күмелгән иде.* М.Мәһдиев

3) *сөйл.* Шундый йомшак күннән тегелгән итек. *Авыр чакта, хром кигәндә дә, Чын йөрәктән сине яраттым.* В.Галиев

4) Хроматлардан ясала торган сары төстәге буяу төре. *Хромга буялган*

**2.** *с. мәгъ.* Хром (*1 мәгъ.*) тозлары белән иләп ясалган йомшак күннән тегелгән, хромнан (*2 мәгъ.*) эшләнгән. *Аның артыннан кайсы хром итек, кайсы җиз кадаклы штиблетлары белән эре сабаклы, сөян төсенә кереп саргайган камылда чаштыртап, башкалар да комбайнны урап әйләнде.* А.Хәлим. *Ә киемнәре шәһәрнекенә тартым: башында, сәләмәрәк кенә булса да, эшләпә, аягында кара хром ботинка, ә өстендә көзге кара пальто.* В.Нуруллин

**ХРОМАТ** *и. лат. хим.* Хром кислотасының сары төстәге тозы. *Хромат эремәсе*

**ХРОМАТИЗМ** *и. гр. махс.* 1) *физ.* Ак төстәге нурның төрле төстәге нурларга таркалу үзлеге. *Аның әсәрләрендәге хроматизм (буяуларның күптөрлелеге) нечкә сиземләү белән характерлана.* К.Гыйззәтов

2) *муз.* Музыкада тавышның, ярымтоннарга бүленеп, күтәрелә яки төшә бару күренеше. *[Салих Сәйдәшев] Татар музыкасында моңа кадәр кулланылмаган хроматизмны кертеп, әсәрләрен гармонияләштерүдә гомумкешелек музыкаль культурасы казанышларыннан иркен файдаланды.* Г.Кайбицкая. *Көйнең моңында кабатланулар белән гармонияләнеп килә торган хроматизм элементлары, җырның яңгырашына күңеллелек бирә торган көчле колоратуралар – болар барысы да С.Сәйдәшевкә оперетта стиле якын булуын күрсәтә.* З.Сәйдәшева

**ХРОМА́ТИК** *с.* 1) Хроматизм (*1 мәгъ.*) күренешләренә нигезләнгән. *Хроматик төсләрдән (яшел, зәңгәр, кызыл, сары) тагын бик күп төсләр ясап булуын сез инде беләсез.* Ялкын

2) *муз.* Хроматизмга (*2 мәгъ.*) нигезләнгән. *Хроматик ярымтонда яңгыравы белән татар традицион музыкасыннан шактый аерылып торсалар да, ул көйләрне халык бик яратып, зур яңалык итеп каршылады.* Ф.Вәлиева

3) *муз.* Ярымтоннар барлыкка китерү өчен үзенчәлекле җайланмалары булган. *Вася дәдәй Варшавский исә ике рәтле хроматик (авазның, тавышның ярты тоннарга бүленүен тәэмин итүче) төзелешле гармун эшләтте.* Ф.Туишев

**ХРОМАТО́ГРАФ** *и. гр. махс.* Хроматография ысуллары ярдәмендә матдәләрдәге катнашмаларны тикшерү, чистарту, анализ ясау максаты белән аеру һәм анализлау өчен кулланыла торган лаборатор прибор. *Күзләре тонык кына гүләп утырган хроматографның экрен-тигез шуышкан угына төбәлгән.* Э.Касыймов. *Лабораториядә матди-техник база ныклы: хроматографлар, фракция составын билгеләүче аппаратлар, фотоэлектр колориметрлары, автомат дозаторлар һәм титраторлар, газ анализаторлары һәм башкалар.* Кызыл таң

**ХРОМАТОГРА́ФИЯ** *и. гр. махс.* 1) Катнашмаларны аеру һәм анализлау белән шөгыльләнә торган фән тармагы. *Уфа фәнни тикшеренү институтында хроматография белән өлешчә шөгыльләндем мин.* Ф.Зыятдинов

2) Эретелгән, сыек хәлгә китерелгән матдәләрнең катнашмаларын аеру һәм аларның физик-химик үзлекләрен билгеләү, анализ ясаудан гыйбарәт метод. *Соңыннан тикшеренүне лабораториягә күчереп, «шизофрения исе» белән газ хроматографиясе ысулы ярдәмендә эшләргә исәплиләр.* Шәһри Казан

**ХРОМИТ** *и. гр. хим.* Составында хром һәм тимер булган кара төстәге минерал, руда; хромлы тимер. *Пермьгә баргач, хромит чыгара торган Сараны шахтасына ук төшкән ул.* Т.Нәҗмиев. *Иң кыйммәтле чималлар – тоз, алтын, алмаз, хромит һәм башка минераллар табыла торган яклар нишләп болай яшь?* Татарстан яшьләре

**ХРО́МКА** *и. рус сөйл.* Ике рәтле гармун төре; хроматик гармун. *Баян дип тә пошмый ул, аккордеон дип тә авыз суын корытмый, аның иң яратып уйнаган гармуны – хромка.* И.Юзеев. *Хромка тиз уйнала торган көйләр, бию көйләрен башкару өчен уңай.* М.Мәһдиев

**ХРОМЛАНУ** *ф. төш. юн. к.* **хромлау.** *– Ә син, кәнтәй, анда Закуан барыгызны да!.. – дип кычкырды Сәях әллә нинди куркыныч тавыш белән һәм, мич арасында яткан балтаны алды да, тимер караватның хромланган ак башларына чабарга тотынды.* Н.Хамалов. *Наталья кыюлана төште: хромланган боргычлы югыч янына килеп, аның ике боргычын да ачып карады – гөжләп салкын һәм кайнар су ага башлады.* Р.Мирхәйдәров

**ХРОМЛАТУ** *ф. йөкл. юн. к.* **хромлау.** *Гата балталарына кадәр заводтан хромлатып алып кайткан.* Н.Хәсәнов

**ХРОМЛА́У** *ф.* 1) Хром (*1 мәгъ.*) белән каплау, хром йөгертеп ялтырату. *Шулай ук якын-тирәдә машиналарны хромлый торган сервислар да юк икән.* Якты юл

2) Хайван тиресен хром тозлары белән иләү, хромда йомшарту. *Тирене хромлау*

**Хромлап алу** Тиз генә, кыска вакыт аралыгында хромлау

**Хромлап кую** Алдан яки тиз арада хромланган хәлгә китерү. *Самавырны хромлап кую*

**Хромлый башлау** Хромларга керешү. *Машина детальләрен хромлый башларга кирәк.* Туган як

**ХРОМЛЫ** *с. хим.* 1) Хром (*1 мәгъ.*) катнашкан, составында хром булган. *Хромлы катнашма белән оксидлаштырганда, пропион, май, изомай һәм изовалериан кислоталары катнашмасын хасил итә торган спиртны атагыз.* Органик химия

2) Хром белән капланган, хром йөгертелгән. *Машинаның хромлы бамперындагы күгәрек тапларны бетерү өчен, бамперны кóлага манылган алюмин фольга кисәге белән сөртегез.* Көмеш кыңгырау

**ХРОМОСО́МА** *и. гр. биол.* Үсемлек һәм терек организмнарның күзәнәк төшендәге нәселдәнлек генетик мәгълүматын буыннан буынга күчерә торган

элемент. *Аның канында кызыл кан күзәнәкләре кими башлаган, нәтиҗәдә генетик код бозылган, хромосома төзәлмәслек булып үзгәргән иде.* Ф.Бәйрәмова. *Болай туганнарны ХО кешеләр дип атыйлар, аларның генетик җыелмасында 46 урынына 45 хромосома була.* Фән һәм тел

**ХРО́НИК** I *с.* 1) Озакка сузылган яки әледән-әле кабатлана торган (авыру тур.). *Сез, иптәш-әфәнде, хроник баш авыртуы белән җәфаланасыз...* Л.Лерон. *Белгеч биргән белешмәдә токтынның каралу вакытында хроник бронхиттан, миокардиттан һәм икенче дәрәҗә трахомадан җәфалануы әйтелгән.* Д.Гарифуллин

2) Даими авыру белән интегә торган (кеше тур.). *Бу бүлектә күбрәк хроник авырулар булганга, шуларның күпчелегенә елына икешәр тапкыр дәваланып чыгу таләп ителгәнгә, берберсен инде күптән үк яхшы белгән әниләр (монда фәкать әниләр генә) байтак иде.* Л.Ибраһим-Вәлиди. *Хәзер Россиядә яшьләрнең 40 проценты психик яктан тайпылышлы, 70 проценты хроник авыру, 30 проценты эшсез, һәм яшь хатыннарның 30 проценты бала табарга кыймый!* М.Вәлиев

3) *күч.* Даими яисә еш кабатланып тора торган; еш, һәрвакыт була торган. *Фәррах бу шешәләрне инде өч ел элек чүп арасыннан алып калган һәм хатыны белән ике арада хроник җәнҗал тудырган иде.* Ф.Садриев. *Барыбызның да гади колхозчы балалары булып, акчага хроник мохтаҗлык кичерүебезне исәпкә алсаң, бигрәк тә.* М.Кәбиров

**ХРО́НИК** II *и. сөйл.* Дәвамлы яки әледән-әле кабатланып торган авыру белән интегүче кеше. *Әлеге категориягә сулыш органнары, бөер һәм терәк-хәрәкәт аппараты авырулары булган хрониклар һәм депрессиягә бирелүчеләр керә.* Шәһри Казан

**ХРО́НИКА** *и. гр.* 1) *тар.* Вакыйгалар хронологик тәртиптә теркәлгән язма; елъязма. *Италиянең Урта гасыр хроникаларында телгә алынган, «болгари» дип аталган затлы күннәр, бизәкле сәхтиян читекләр каян килеп кергән дип беләсез?!* М.Юныс. *Императорның сәркатибе ике арада булган сөйләшүләрне хроникасына терки барды, һәм император үзе дә һәрдаим кырын карады.* М.Хәбибуллин

2) Тарихи, сәяси, иҗтимагый һ.б.ш. вакыйгаларны тасвирлаган әдәби әсәр. *Шул елның 3 сентябрендә нигезен әлеге кечкенә хроника тәшкил итәчәк зур роман язарга уйлый.* М.Хуҗин. *Әйтергә кирәк, чагыштырмача матур хроника!* Р.Фәйзуллин

3) *сөйл.* Төрле хәлләр, агымдагы тарихи вакыйгалар эзлеклелеге. *Әлеге вакыйгалар хроникасын карап үтик: 1467 елда Казанда, Мәхмүд хан үлгәч, тәхет өчен янә көрәш башлана.* Т.Әйди

4) Журналда, газетада көндәлек вакыйгалар турындагы хәбәрләр, бүлдерүләр бүлеге. *Биредә газета хроникасына теркәлгән иң беренче вакыйга 1935 елның 27 июнь датасы белән тамгаланган.* Ә.Рәшит. *Журналның хроника өлешен оештыруны да ныклы бер тәртипкә саласы бар.* Р.Фәйзуллин

5) Вакыйгаларны хронологик тәртиптә күрсәтә торган документаль фильм; гомумән, берәр тарихи вакыйганы чагылдырган документаль фильм. *Сугыш турындагы хроникаларны карап һәвәсләнгән авыл малайлары икенче көнне үк Жуков, Малиновский, Рокоссовский булып таяк атка атланып, Сталинград, Кавказ, Берлиннарга барып җитәләр иде.* Д.Гыйсметдин. *«Казанский телеграф» газетасы хәбәр итүенчә, 1909 елда Казан гарнизоны гаскәрләренең тантаналы парады хроника тасмасына төшерелгән.* Казан утлары

**ХРОНИКАЛЬ** *с.* Вакыйгаларны хронологик тәртиптә күрсәтә торган; хронологик тәртиптәге; гомумән, документаль. *Өченче томның ахырында шагыйрьнең басылып чыккан китаплары исемлеге, бик тулы биобиблиографик һәм хроникаль мәгълүмат урнаштырылган.* М.Шабаев. *Аерым фәннәр һәм сәнгать төрләре буенча махсус басмалар булмагач, киң мәгънәдәге рухи культурабызның хроникаль елъязмасын шушы журналдан укымыйча, бүтән нинди чыганактан беләсең?!* Р.Фәйзуллин

**ХРО́НИКАЧЫ** *и. сөйл.* 1) Хроника (*1 мәгъ.*) алып баручы, хроника язучы. *Хроникачы хуҗалыкның бөлгенлеккә төшүен менә ничек сурәтли: «Виноградлыклар эшкәртелми, кырлар сукаланмый ---».* Урта гасырлар тарихы

2) Билгеле бер мөһим вакыйганы төшереп баручы, вакыйга барган урыннан хроника биреп баручы; кинооператор. *Бөек Ватан сугышы хроникачысы*

3) Вакытлы матбугатта хроника бүлегендә эшләүче; шул бүлеккә материаллар әзерләүче; көндәлек хәбәрләр биреп торучы. *Роллинг илтифат итмәгән вак-төяк хроникачыларны яллады: алар, черки кебек, дөньяның һәрбер ярыгына үтеп керәләр дә зур журналистлардан ныграк файда китерәләр иде.* А.Толстой

**ХРОНО́ГРАФ** I *и. гр.* 1) Кыска вакытлы күренешләрне теркәп һәм аларның дәвамлылыгын үлчәп, язып бара торган махсус әсбап. *Һәр иртәдә гаилә башлыгы Джон Генри Гринвич обсерваториясенә бара, анда үзенең югары төгәллекле хронографын дөресли.* Мәдәни җомга. *Кинойолдыз һәм автоузышчы Пол Ньюманның Rolex хронографы рекордлы сумма – 17 752 500 долларга сатылган ---.* Заман сулышы

2) *күч.* Теркәп, язып баручы. *Ләкин мин – булган хәлләрне теркәп баручы хронограф кына, очраклы гына килеп чыгып гаҗәпкә калган шаһит.* Д.Вәлиев

**ХРОНО́ГРАФ** II *и. гр. махс.* Тарихи вакыйгаларга, бөтендөнья тарихына, билгеле бер илнең тарихына күзәтү ясап чыккан борынгы китап, язма; елъязма. *Никон елъязмасы чыганакларын берничә төркемгә бүләргә мөмкин: Лаврентьево-Троицк төркеме чыганаклары, Новгород-София чыганаклары, Ростов төркеме, Бөек Мәскәү кнезе җыентыклары, хронографлар, шәҗәрәләр.* Б.Хәмидуллин

**ХРОНОГРА́ФИК** *с.* 1) Хронография тәртибендә язылган. *Никон җыентыгында хронографик материалның ике төре кулланылган.* Б.Хәмидуллин

2) Хронограф (I) ярдәмендә башкарыла торган. *Хронографик мәгълүмат*

**ХРОНОГРА́ФИЯ** *и. гр.* Билгеле бер вакыт аралыгында булган вакыйгаларның эзлекле рәвештә еллап язылган исемлеге. *Хәйрия фонды акча җыю белән шөгыльләнә икән, аның тарихы, эшчәнлек хронографиясе, финанс исәп-хисаплары, контактлары күрсәтелгән рәсми сайты булырга тиеш.* Мәдәни җомга

**ХРОНОЛО́ГИК** *с.* Хронологиягә нигезләнгән. *Хронологик тәртиптә булмаса да, кайберләрен әйтеп карыйм: «Раушаниям, бәгырем» җырын алтмышынчы еллар башында Актаныш районында әдәбият көннәрендә үзешчәннәр башкаруында ишеттем.* Ш.Галиев. *Шуңа да икенче бүлектә хронологик чикләр киңрәк чорны, әйткәнемчә, ике дистә елны иңләп ала.* А.Әхмәдуллин

**ХРОНОЛО́ГИЯ** *и. гр.* 1) Вакыт эзлеклелеге саклап язылган вакыйгалар исемлеге, елъязма. *Әлеге хроно-*

*логиядән күренгәнчә, Г.Ибраһимовның педагогик эшчәнлеге Балтач районында башлана һәм үсә.* Г.Мөхәммәтшин. *Орхон язмаларының һәм Дунай буе болгарларының хронологиясен чагыштырып, елның һәр икесен дә Сыер елы икәнлеген күрәбез, димәк, циклның башы, чыннан да, Тычкан елы булган.* А.Тимергалин

2) Вакыйгаларның булу, килеп чыгу вакытының эзлеклелеге; берәр эштә шул эзлеклелекне саклау принцибы. *Асия җиңги моны эшләгәндә хронология саклады: Кәшфинең иң беренче грамотасы 1939 елда ук алынган икән.* М.Мәһдиев. *Ясаган барлык нәтиҗәләрен, фикри йомгакларын ул аргументлар белән генә түгел, ә бәлки саллы фактура (библиография, хронология) белән дә ныгытып куя.* Т.Кәримов

3) Тарихи вакыйгаларның булу вакытын һәм документларның язылу вакытын билгели торган һәм шуны өйрәнә, өйрәтә торган тарихи дисциплина. *Шул ук вакытта тарих белеменең чын фәннилеккә туры килә торган махсус тармаклары да бар. Мәсәлән, хронология, метрология, археология шикелле махсус тармаклары.* Р.Вәлиев. *Заманында тарихи хронология фәне белән мавыгып, бу датаны һиҗридән григориан ел хисабына күчереп карагач, туры килмәве ачыкланды.* Гасырлар авазы

**ХРОНО́МЕТР** *и. гр.* 1) Бик төгәл йөри торган кесә сәгате. *Минем хронометр буенча әле тагын ике минут ярым вакыт бар иде, сез тиз уйнадыгыз!* Р.Батулла

2) Бик төгәл йөри торган балансирлы астрономик сәгать. *Үтә төгәл хронометр ачык океанда безнең кайсы ноктада булуыбызны билгеләргә ярдәм итүче йолдыз вакытын саклый.* Р.Мостафин. *Элек хронометр дип атала торган төгәл сәгать белән вакыт билгеләп һәм секстант дип атала торган оптик җиһаз аша Кояш, Ай яисә йолдызларны күзәтү һәм хисаплаулардан соң, транспорт чарасының Җир өслегендәге урынын билгеләү штурманнарга нәтиҗәне «соңарып» бирә иде ---.* Татарстан яшьләре

**ХРОНОМЕТРАЖ** *и. фр.* 1) Кул белән яки машина ярдәмендә башкарыла торган бертөрле эшләрне башкаруга киткән вакытны исәпләү методы. *Предприятиеләрдә моны хронометраж ярдәмендә бик төгәл исәпләп баралар.* Н.Дәүли

2) Нәрсәгә дә булса сарыф ителгән вакыт аралыгын үлчәү, исәпләү. *Балалар уеннарын үткәрү өчен, «Олимпик-парк» спорт үзәгендә Олимпия резервының тау чаңгысы мәктәбенең яңа бинасы төзелде, чаңгы юллары 15 метрга киңәйтелде, яктылык, тавыш, хронометраж системалары урнаштырылды.* Кызыл таң. *Моңа фермада эшләүчеләргә укыту курслары уздыру, һәр хезмәткәр һәм шулай ук технологик процессның эш вакыты билгеләнгән хронометраж төзү (эш вакыты, саву стандарты, яшь бозауларны эчерү, кабат җитештерү, яшь терлекләрне ашату) керә.* Заман сулышы

3) Телевизион тапшыру, фильм һ.б.ш. эшләрнең вакыт буенча күләме; минутлап, секундлап төгәл исәпләнгән вакыты. *Монда төрле формат, хронометраж һәм жанрда төшерелгән 10 фильм керде.* Татарстан. *Тапшыруның хронометражы якынча 40 минут, һәм ул атнасына биш тапкыр эш көннәрендә эфирга чыгачак.* Мәйдан

**ХРОНОСКОП** *и. гр.* Бик кыска вакыт арасын үлчәү өчен кулланыла торган прибор. *XX гасыр уртасына кадәр астрономия, физика, эксперименталь биологиядә хроноскоп кулланылган.* Фән һәм тел

**ХРУСТАЛИК** *и. рус* Күз карасының артында урнашкан һәм яктылык нурларын челтәр катлауга юнәлтү вазифасын башкара торган ике ягы да кабарынкы үтәкүренмәле тәнчек, күз ясмыгы. *Катаракта операциясе шуннан гыйбарәт: күз алмасына ике кечкенә тишек ясап, инде яраксызга әйләнгән хрусталикны суыртып чыгаралар да аның урынына ясалма хрусталик урнаштыралар.* Ватаным Татарстан. *Белгечләр катарактаны икенче төрле күз ясмыгының (хрусталик) тоныклануы дип атый.* Безнең гәҗит

**ХРУСТАЛЬ** *и. гр.* Бәллүр. *Хикмәт шунда, борынгы байлыкны күргән карт әйбер танырга бик оста иде: асылташларның чынмы – ялганмы икәнен, фарфор, хрусталь кебек зат әйберләрнең чын сыйфатын һәм кайсы илдән чыкканлыгын, өй җиһазларының нинди агачтан һәм нинди стильдә эшләнгән булуын бер караудa әйтә дә бирә.* Ә.Еники. *Гаҗәеп саф, хрусталь чыңлаган яки бик юка боз ватылып коелган авазлар чыгарып чыңлый йолдызлар...* М.Хәсәнов

**ХУДО́ЖЕСТВО** *и. рус* 1) Сәнгать. *Художество әсәрләрендә сурәтләр өч төрле: аерым шәхесләр, аларның эш һәм хәрәкәтләре, сүзләре.* Г.Нигъмәти. *Г.Ибраһимов «хәят белән реаль әдәбият арасындагы мөнәсәбәтне художество әсәрләрендә чорның актуаль проблемалары яктыртылуда күрә дә».* Фән һәм тел

2) Гомумән, сәнгать әсәрләре яки аларны иҗат итүчеләрнең иҗади манералары. *[Г.Камал] әсәрләрендә яхшы ук эшләнгән художество образлары аша тормышка тәнкыйть күзе белән карау һәм критик реализм методы сизелеп тора.* М.Гали. *Язучының роман жанрына күчүе, бердән, революцион күтәрелеш елларында матур әдәбият алдында торган бурычларның зурлыгы белән аңлатылса, икенчедән, моңа Ибраһимовның художество осталыгы үсүе дә сәбәп булды.* М.Хәсәнов

**ХУДО́ЖЕСТВОЛЫ** *с.* 1) Сәнгать таләпләренә төгәл туры килгән, сәнгать әсәрләренә хас булган, сәнгатьле, сәнгатьчә. *Чөнки художестволы сөйләм үзенең киң кулланышта булуы һәм сәнгатьчә яңгырашы ягыннан телдәге башка стильләрдән аерылып тора.* В.Хаков. *Поэмада шушы килеш тә ятлап алырлык матур урыннар күп, ләкин алар гына поэманы югары художестволы әсәр итә алмыйлар.* Р.Харис

2) Нәфис, зәвык белән башкарылган, матур итеп эшләнгән, сәнгатьле, сәнгатьчә. *Өйнең эчке бүлмәләрендәге бөтен ишекләр, орнаментлаштырылып, көрән төстәге имәннән эшләнгән; түшәмнәрдә, уңмый торган кыйммәтле путал каймалар белән уратылып, художестволы табигать күренешләре сурәтләнгән.* Ш.Камал. *«Горреклама» художестволы рекламалар, элмә такталар, аңлатма язулар һәм лозунглар язу-ясау белән шөгыльләнә.* Р.Батулла

**ХУДО́ЖНИК** *и. бор. слав.* 1) *к.* **рәссам**. *«Художник» дип йөртсәләр дә, төрле плакатлар ясарга өйрәнеп килсәм дә, кызларның гашыйк карашыннан очынып йөрсәм дә... нидер җитми, хыял каядыр ашыга, үз-үземне узарга, кемнедер шаккатырырга теләп, майлы буяуларга тотынам.* М.Галиев. *Ә син, Гамбәр, кара нинди, синең сурәтеңне төшерергә дип башкаладан кадәр художник килгән, ә?!* З.Мурсиев

2) Сәнгатьнең берәр өлкәсендә иҗат итүче; сәнгатькәр. *Чын художник, чын әдип, минемчә, халкыннан аерылырга тиеш түгел...* М.Хәсәнов. *Әлбәттә, оста художник кеше күңелендәге кичерешләрнең бик тирәндә ятканнарын да*

*тотып ала, бирә белә, шуңа да карамастан, минем уйлавымча, язарга сәләтле һәм үтә тоемчан кешеләргә автобиографик җирлекле әсәр белән язучы уйдырмасы нигезендә туган повесть яисә романны аеру кыен түгел.* Р.Рахман

**ХУҖА** *и. фар.* 1) Хосусый милек иясе, милке булган кеше; берәр шәхси мөлкәткә ия кеше. *Шуңа күрә басмаханә хуҗасына хәрефләр бик кыйммәткә төшә.* Г.Алпаров. *Сезнең күршегездә көнбагышлар чәчкә атып утыра, әмма хуҗа үзе өйдә юк, күрәсең.* А.Хәлим // Нәрсәнең дә булса иясе. *Ат хуҗалары атларының йөгәнен рәтләп, ялларын тараган булалар, тынычсызланып сыйпаштыралар.* Г.Бәширов. *Гөлия кичәге машина хуҗасының үзенә исеме белән дәшүен хәтерендә яңартты.* Г.Әдһәмова

2) Яллап эшләтүче. *Ә хуҗалар безне коллар итеп, Хайваннар дип читкә саттылар.* Г.Кутуй. *Ә колга хуҗалар һәрчак табылып тора.* В.Имамов

3) Шәхси хуҗалыгы булган крестьян. *Авылда ул урта хуҗа исәпләнә: яхшы аты бар, яхшы сыер, сарыклары.* И.Гази

4) Нинди дә булса зур хуҗалык, оешма өчен җаваплы кеше, җитәкче, оештыручы. *Тегесенең дә әйтер сүзе әзер: син – хуҗа, син баш кеше, теләсәң каян табарга тиешсең, янәсе.* М.Хәсәнов. *Ул ялварулы бердәнбер күзен хуҗасына төбәде: – Зинһар кичерә күрегез, шеф... гафу...* А.Гыймадиев

5) Ил башы, идарәче, хаким, хакимият вәкиле. *Урын аулак, иптәшләр үзебезнеке, дуслар ышанычлы, сый мул, үз кесәңнән түгел, мунча илаһи шәп, тормышның кадерен белеп, илгә, ил хуҗаларына рәхмәт укып яшә дә яшә генә!* А.Гыйләҗев. *Илдә хуҗалар ишәйсә, Хуҗасыз этләр арта.* Г.Морат

6) Йорт башы, гаилә башлыгы. *Хуҗа тәмле аш пешергән хатынының маңгаена агач кашык белән тондыра.* Т.Галиуллин. *Әниебез синнән башка Бернәрсә дә хәл итми: Кая барсам, нишләсәм дә, Әтиеңнән сора, ди, Ул бит безнең хуҗа, ди, Ул әйтсә, мин риза, ди.* В.Хәйруллина

7) Билгеле бер урында, эштә һ.б.ш. вакытлыча җаваплы булган, барысын да үзе теләгәнчә эшли ала торган кеше. *Шулай да элемтәче каешланган адәм булса кирәк, үзенең биредә хуҗа булуыннан файдаланды: Мөслимовны телефонга куеп, үзе ятып йоклады.* Х.Камалов. *Фаяз Гыймранович, үзегез өстәлгә хуҗа булыгыз әле, әнә рюмкалар, сала торыгыз.* Р.Сәгъди

8) Дәрәҗәсе, белеме, тәҗрибәсе, авторитеты һ.б. белән башкалардан өстен булган, сүзе үтә торган, башкаларга үз фикерен үткәрә ала торган кеше, башкалар өчен төрле мәсьәләләрне хәл итүче кеше. *Ул соң Гомәр абзыегыз шундый ук сезгә хуҗа булырлык кешемени, сүзеннән чыга алмыйсыз?* Г.Камал. *Ләкин мин үзем, үз гаиләм турында кайгыртам, мин башкаларга хуҗа түгел.* М.Хуҗин

9) *сөйл.* Хатын өчен – никахлы ир. *Ул хәтта күкрәк кесәсеннән бер фоторәсем дә алып күрсәтә, менә минем хуҗам, ди.* Х.Камалов. *Хуҗам минем, әллә син исерек инде?* З.Хәким

10) *сөйл.* Аллаһы Тәгалә, Ходай. *Илаһым, хуҗам, үзең хәерен насыйп ит...* М.Хәсәнов. *Ак дөньяны үз итмәгән өчен Үзең кичер, Раббым, Бер Хуҗам!* Ф.Гыйләҗев

11) Остаз, мулла, хәзрәт. *Моңа җавап бирер өчен, Хуҗа Насретдин шикелле хикмәт иясе булырга кирәк.* Г.Әпсәләмов. *Төрки дөньяда хикмәтле сүзгә нигез салучы булып Хуҗа Әхмәд Ясәви исәпләнә.* А.Тимергалин

12) Кешеләр өчен мөһим, әһәмиятле, бөек, серле тоелган нәрсә; өстен көч. *Бу олы дөньяга, чынбарлыкка үзенең, ягъни адәм баласының түгел, ә табигатьнең чын хуҗа икәнлеген онытa кеше дигәнең!* М.Вәлиев

13) Ихтыярлы, үз-үзенә карата җаваплы булу сыйфаты. *Чир тигән кеше үз авыруының тамырына үзе барып җитә ала икән – бу кеше тәненә дә, җанына да хуҗа була ала дигән сүз!* А.Гыйләҗев. *Гафу ит, мин үземә үзем хуҗа түгел.* Аманулла

14) *күч.* Аеруча мөһим саналган, әһәмиятле булган, зур роль уйнаган нәрсә. *Шул пычрак кәгазьләр хуҗа булган дөньяда яшисем килми.* Р.Габделхакова

**ХУҖАЛА́РЧА** *рәв.* **1.** 1) Хуҗа кебек, үз итеп, иркен. *– Бу сиңа келтеркелтер барган трамвай түгел шул, – диде ул, үзен бөтенләй зурларча һәм хуҗаларча хис итеп.* А.Әхмәтгалиева. *Анда мин үз һавамны сулыйм, җирдән хуҗаларча атлыйм.* Р.Галиуллин

2) Хуҗа җитәкче кебек, тартынмыйча; хуҗа кешегә хас рәвештә. *Арбага утыргач та, Җәләлетдинов идарәдән ияреп чыккан кешеләргә хуҗаларча кыска-кыска гына боерыклар бирде, шуннан соң без кузгалып киттек.* Ә.Еники. *Ихтыярга сәерсенеп карап торды да, ике кулын хуҗаларча артка куеп, кабинеттан чыгып китте.* В.Вәлиев

3) *күч.* Җаваплылык, осталык, саклык белән, алдан күреп. *Аның каләменнән төшкән башлам яисә соңгы сүздә фикерләү киңлеге, әдәбиятка хуҗаларча карап, аның көчләрен барлап, юнәлеш биреп, киләчәк үсеш юлларын тамгалап баруы искитмәле.* Т.Галиуллин. *Бу – җитәкченең булган мөмкинлекләреннән хуҗаларча файдалануы нәтиҗәсе.* Т.Нәҗмиев

**2.** *с. мәгъ.* Хуҗаларга хас; сакчыл, кайгыртучан. *Ләкин бер нәрсә бик эчне пошыра: табигатьнең үз-үзен савыктыруга көчле омтылышы һәм кешеләр ярдәме белән үстерелгән урман байлыгына халыкта хуҗаларча мөнәсәбәт, кадер һәм сак карау җитеп бетми.* Татарстан яшьләре. *Табигатькә хуҗаларча карашның әле бервакытта да артык булганы юк.* Шәһри Казан

**ХУҖАЛЫК** *и.* 1) *икът.* Халыкны яшәтү, тәэмин итү өчен кулланылган, кеше тарафыннан ясалган барлык җитештерү чаралары һәм җитештерү ысулы. *Социалистик икътисадның җимерелүе, капиталистик хуҗалыкның тиз генә аякка басып китә алмавы Румыния матбугатын, шул исәптән әле тернәкләнергә өлгермәгән «Кара дәниз»не дә бик авыр хәлгә куйган ---.* Т.Әйди. *Җәләш мулла – җимерелеп барган феодаль хуҗалыкка корылган, ислам идеологиясенә һәм шәригать кануннарына нигезләнгән патриархаль гаилә хуҗасын һәм ярлы халык җилкәсендә яшәүче руханилар катлавының бер вәкилен чагылдыручы әдәби тип.* Фән һәм тел

2) Җитештерү өчен хезмәт итә торган, икътисадны тәшкил итә торган барлык нәрсә. *Әгәр Совет чорында халык хуҗалыгының берәр тармагында уңыш казанылган икән, һичшиксез, икенче өлкәсендә торгынлык яки хәтта чигенү күзәтелмичә калмый.* А.Тимергалин

3) Җитештерү төренең билгеле бер тармагы. *Гражданнар сугышы, аннан соңгы авыр елларда шәһәр хуҗалыгы тәмам ташландык хәлгә килә.* Р.Мостафин. *Хәтерлисең булыр, илленче елларның азагында, авыл хуҗалыгын алга җибәрү өчен кукурузны күбрәк чәчәргә кирәк, дип аңлата башладылар.* В.Нуруллин

4) Күмәк хуҗалык; колхоз. *Шәмсүн яхшы белә: тирә-юньне зур игъти-*

*бар белән күзәтеп баргандай күренгән хәйләкәр бу бәндә син хуҗалык башында утырганда дус булып кыланыр, ә киргәнең беткәч, җәй гына читкә шылачак.* А.Вергазов. *Хуҗалык рәисе Фәрит Шәйхетдинов ут бөрчәсе кебек егетне шул елны файдалануга тапшырылачак Өтернәс сөтчелек комплексына механик итеп билгеләде.* Т.Нәҗмиев

5) Нинди дә булса предприятие, оешманың мал-мөлкәте, җитештерү кораллары, җиһазлары. *Төшкелекне ашап алды да бригада хуҗалыгы белән, язу-сызулар белән таныша башлады.* Н.Фәттах. *Бүген «Идел-Пресс» нәшрияты урнашкан урында 1950 елларга кадәр 387 нче заводның хуҗалыгы булган.* Шәһри Казан

6) Гадәттә авылда яшәгән, бер гаиләдән торган, үз мал-туары, йорт-каралтылары һ.б. булган берәмлек. *Колхоз ярдәмендә авылларның һәр хуҗалыгы яңа, заманча йортлар салып чыкты.* Г.Мөхәммәтшин. *Чөнки һәркайсының үз хуҗалыгы, терлек-торышы бар, һәркайсының колхоз председателенә йомышы төшә: я машина, я ат, я саламы-печәне, я тегесе, я монысы кирәк.* В.Нуруллин

7) Йортта, көнкүрештә кирәк булган эш кораллары, өй кирәк-яраклары, азык-төлек һ.б.ш. *Әткәйнең хуҗалык кирәк-яракларын саклый торган келәтендә һәммә нәрсә үз урынында иде.* М.Әмирханов. *Хәкимҗанның, кулга хуҗалык сумкасы тотып, төнге каравылдан – машина паркыннан кайтып килеше иде.* Н.Хәсәнов

8) Йортны алып бару, йорт эшләрен башкаруга бәйле булган вазифалар, эшләр. *Йортта барысы өчен дә мин җавап бирәм, бөтен хуҗалык минем өстә.* Ф.Садриев. *Элек гаилә – әби, бабай, әти, әни, балалар, йорт һәм йорт әйләнәсендәге хуҗалык булса, хәзер кешенең әти-әнисенә игътибар күрсәтергә, балалар тәрбияләргә, йорт эшләрен башкарырга, хуҗалык эшләрен алып барырга вакыты юк.* Л.Әбүдәрова

◊ **Хуҗалык сөрү** Хуҗа булу, хуҗа булып тору. *Әле монда һаман Садыйк бай хуҗалык сөрәмени?* Ш.Камал

**ХУҖАЛЫ́К ИТҮ** *ф.* 1) Нинди дә булса хуҗалык эшендә эшләү; хуҗалык эшен алып бару. *Шул яшьтән бәйсезлеккә ирешү, үз башына дөнья көтү һәм хуҗалык итү ул заманда, әлбәттә, зур бәхеттән саналган булырга тиеш.* Ә.Еники. *Без әлегә беркатлы сәясәт алып барабыз, массаларның аңында борылыш ясарга кирәк, дип лаф орабыз, үзебез исә хуҗалык итүдә бертуктаусыз ялгышлар җибәрәбез.* Ф.Сафин

2) Нинди дә булса оешма, берләшмә һ.б.ш. белән җитәкчелек итү. *Аның чын оештыручы, талантлы педагог, оста хуҗалык итә белүче җитәкче сыйфатлары нәкъ менә шушы чорда ачыла.* Г.Мөхәммәтшин. *Бер атна гына монда Кәрамәт тә хуҗалык итеп тора алачак ич.* Л.Хәмидуллин

**ХУҖАЛЫКЛЫ** *с.* 1) Хуҗалыгы булган, хуҗалыклардан торган. *Йөз хуҗалыклы авылда колхоз төзеп бетерә алмасыннар инде, я!* М.Хуҗин. *Мең хуҗалыклы нинди зур авылда күп балалы гаиләләрне, саный башласаң, бер кулдагы бармаклар да җитә.* М.Афзалова

2) *к.* **хуҗалыкчыл**. *Була: авылның иң уңган, хуҗалыклы кешесе йорт торгызу өчен ары чабып, бире килеп тир түгеп йөргәндә, авылның иң булдыксыз, ике бозауга кибәк аера белмәгән Гыйльметдине шәһәргә барып өч бүлмәле фатир алган.* А.Гыйләҗев. *Кофены үзе төеп, үзе әзерләве турында сөйләгәндә үк мин аның хуҗалыклы ир булуын аңладым.* Э.Шәрифуллина

**ХУҖАЛЫКЧАН** *с. к.* **хуҗалыкчыл**. *– Гаян өенә апкайтмакчы, хатынына ярамакчы була, бигрәк хуҗалыкчан шул, – дип шаркылдый ул.* Р.Газиз. *Кирәк чакта ата назын, кирәк чакта ата каешын татымаганга күрә, хуҗалыкчан булып үсмәгән дә инде ул менә.* Л.Лерон

**ХУҖАЛЫКЧЫ** *и.* Хуҗалык эшендә эшли торган кеше; хуҗалык алып баручы. *Башында көн саен мең төрле кызыклы уй, хыял туып тора торган егеткә Алма апа белән ялгыз хуҗалыкчы булып, үз яшьтәшләре – комсомоллардан көлдереп йөрү туйдырган.* Г.Ахунов. *– Ул берние белән дә яхшы түгел, аерым хуҗалыкчылар, ичмасам, рәхәтләнеп ипи ашыйлар, куас эчәләр, – дип сөйләде.* А.Фәләх

**ХУҖАЛЫКЧЫЛ** *с.* Хуҗалыкны яхшы алып бара торган, йорт җанлы; хуҗалык эшенә һәвәс, хуҗалык турында даими кайгыртучы. *Хуҗалыкчыл энемнең ышанычлы адымнар белән һаман алга баруы тәэсир иттеме, куйган максатымнан алай тиз генә кире кайта алмаумы, аякларым үзләреннән-үзләре энем артыннан алып китте.* М.Яһудин. *– Синең Мидхәтең хуҗалыкчыл шул, – диде ул.* М.Маликова

**ХУҖАСЫЗ** *с.* **1.** 1) Хуҗасы, иясе булмаган; кеше яшәми яки файдаланмый торган. *Иясез песиләрне, хуҗасыз этләрне иркәләп, балаң алдында яхшатлы булып йөрү җиңел ич ул!..* А.Гыйләҗев. *Әгәр хуҗасыз утрау тапсаң, ул – синеке.* Р.Вәлиев

2) Тәртибе булмаган, начар алып барылган (өй, предприятие һ.б.ш. тур.). *Таланган һәм хуҗасыз илебез Нинди авыр хәлләр кичерә?* Х.Җәгъфәр. *Ә Төркәйнең аннан-моннан җыеп әвәләнгән кысан һәм хуҗасыз фермасында һаман мал кырылды, һаман мал кырылды...* В.Имамов

**2.** *рәв. мәгъ.* Хуҗа булмаган хәлдә. *Борынгылар, елан – җирнең хуҗасы, дип уйлаганнар, һәм аны үтерү, рәнҗетү яки куып җибәрү җирне хуҗасыз калдыруга тиң булган.* А.Тимергалин. *– Авылыгызда бер хуҗасыз торган йорт бардыр әле, – диген.* Р.Фәизов

**ХУҖАСЫЗЛЫК** *и.* 1) Гомумән хуҗасы булмау. *Беркөн, ишек төбендә хуҗасызлыктан аптырап аунап яткан тырмага баскач та, әйтәсе сүзләрне әйтү урынына: «Гафу итегез, ялгыш...» – дип мыгырданып кына куйдым.* И.Шиһапов

2) Нинди дә булса эштә, оешмада таркаулык, башбаштаклык; яхшы хуҗа булмау. *Илдә башланган хуҗасызлык һәм башбаштаклык ябык атом зоналарына да килеп җитә.* Ф.Бәйрәмова. *Яшь татар журналистлары түгәрәге «Яңаваз»ны оештырып йөрүләр, аңа каршы торучылар белән көрәш күренешләре, безнең илдәге хуҗасызлык шартларында һәрбер кечкенә генә эшне башкарып чыгу кыенлыклары белән очрашулар.* М.Вәлиев

**ХУЛИГАН** *и. ингл.* Җәмәгать тәртибен тупас бозучы, хулиганлык эшләүче кеше. *– Димәк, аны берәр хулиган кибеттән кайтып килүче яки кибеткә баручы картның кулыннан тартып алган, – диде Нурия, белдекле күренергә тырышып.* Ф.Яруллин. *Һәм ул кешеләрне бернинди тәрбия дә төзәтә алмый: каракны – урлашудан, хулиганны сугышудан туктатып булмаган кебек, йомшак холыклы кешедән – хулиган, хулиганнан йомшак холыклы кеше ясап булмый.* Ф.Садриев

**ХУЛИГАНЛАНУ** *ф.* 1) Хулиганлык эшләү, җәмәгать тәртибен тупас бозу. *– Алар сезгә басуда хулиганланырга ирек бирмәсләр, – дип шелтәләде.*

Ф.Галиев. *Әй синең малаең, хулиганланып, эчеп-сугышып йөри.* З.Хәким

2) *күч.* Шуклану, шаярып алу. *Бар энергиясен, вакытын, яратуын безгә сарыф иткән, сыйныф бүлмәсен бизим дип, үз өеннән гөлләрен, картиналарын мәктәпкә ташып бетергән, безнең белән көлгән, уйнаган, кайчак хәтта хулиганлана да белгән гаҗәеп бер «яшьти» йөрәкле кешебез булды ул.* Шәһри Казан

**Хулиганлана бару** Торган саен күбрәк хулиганлану. *Малайлары хулиганлана бара*

**Хулиганлана башлау** Хулиганланырга тотыну. *Балалар хулиганлана башлады*

**Хулиганлана төшү** Бераз хулиганлану; тагын да хулиганлану

**Хулиганланып алу** Аз гына, берара хулиганлану. *Минем яшьтә аз гына «хулиганланып» алырга да ярый инде.* Шәһри Казан

**Хулиганланып йөрү** Озак вакыт дәвамында хулиганлану. *Хулиганланып йөрергә вакытым юк минем.* З.Хәким

**ХУЛИГАНЛЫК** *и.* 1) Кешенең характерындагы җәмгыятьтә кабул ителгән тәртипләр белән санашмау гадәте. *Мин беләм: теләсә нинди хулиганлык сүздән, сөйләшүдән башлана.* Н.Акмал.

2) Җәмәгать урынында эшләнгән тупас тәртипсезлек. *Бервакыт хулиганлык кылган егетне судка алып килә бу.* З.Сәмигуллина. *Матвей Ивановичның аптыраулы соравына: «Тагын хулиганлык итә», – дип җавап бирдем.* Кызыл таң

3) *күч.* Шуклык, артык тәвәккәллек, малайлык. *Күпмедер җүләрлек, күпмедер хулиганлык – болар бөтенесе дә минем холыкта калды...* Р.Вәлиев

**ХУ́НТА** *и. исп.* 1) Испаниядә һәм испан телле кайбер Латин Америкасы илләрендә иҗтимагый-сәяси оешмалар, берләшмәләр атамасы. *Бездә бит бөтен нәрсә дә хунта сыман корылган.* Безнең гәҗит

2) Хәрби реакцион террористик оешма. *Дөньяда исә «хунта» сүзе хакимият түнтәрелеше оештырып, җитәкчелекне үз кулларына алган һәм террор, репрессия ысуллары ярдәмендә идарә итүче хәрбиләр төркеменә карата кулланыла.* Безнең гәҗит

3) Хәрбиләр ярдәмендә хакимияткә килгән һәм диктатура урнаштырган сәяси оешма. *Хәрби хунта, баш күтәреп, власть алырга тырышып караган иде, ләкин заговорчы капитал ялчыларын халык тар-мар итте.* Г.Афзал. *Искә төшерсәк, хәрби хунта тарафыннан һәлак ителгән Чили шагыйре һәм җырчысы Виктор Харага багышлап кына да күпме шигырь язылды ул чорда!* И.Вәлиулла

4) *күч.* Үзара килешеп, билгеле явыз максатларда эш алып баручы кешеләр төркеме

**ХУП** *мод. сүз.* **1.** Нинди дә булса эшкә яки сүзгә карата ризалыкны, канәгатьлекне белдереп әйтелә: яхшы, ярый. *– Бик хуп, котлыйм сезне, – дип, Рәйсә ханым да, һични сиздермичә, шат елмайган булды.* В.Имамов. *Хуп, ике арада килешү төзедек, Нәзирә апа.* Н.Гыйматдинова

**2.** *с. мәгъ.* Яхшы, кулай, әйбәт, кабул ителерлек. *Бу – бик хуп күренеш, әлбәттә.* З.Мәхмүди. *Аңлады булырга кирәк: җәмәгатьчелеккә каршы бару – аның өчен хуп гамәл түгел икән шул, ашның күплеге аркасында зиһененә зыяны тигән, ни әйткәнен, кирәкмәс җирдән үртәп алырга маташуын үзе дә сизми калган.* Ф.Яхин

**3.** *рәв. мәгъ.* Дөрес, хак. *Һи җаным, хуп әйтәсең.* К.Насыйри. *Әйе, әйе, мелла кем, Дәүләтьяров әфәнде, хуп сөйлисез.* И.Гази

◊ **Хуп күрү** Яхшы дип уйлау, кулай күрү, яхшыга санау. *Әй башсыз кеше, үз чиратында, башлыларның үзе кебек башсыз булуын хуп күрә.* К.Сатиев. *Сораша башласалар, ул дәшми калуны хуп күрә.* Д.Булатова. **Хуп, мәйле** «Ярар алайса, ничек телисез, шулай эшләгез» дигән мәгънәне белдерә. *– Рәхмәт, күрше, бүтән вакытта. – Хуп, мәйлең.* Н.Әхмәдиев. *Барыгызның да теләге шундый икән, хуп, мәйле, шунда күмегез алайса.* Ф.Баттал. **Хуп табу** *к.* **хуп күрү**. *Дивар буйлап тезелгән урындыклардагы яшьрәкләр бабай-әбиләргә олылап урын бирделәр, өлкәнрәкләр, дүртесе дә, басып торуга караганда, утыруны хуп таптылар.* М.Хуҗин. *Тик хәзер инде Дилемманың тукмалып яшәрлек тазалыгы юк иде, ул, бар көчен биреп, ирен яхшы юлга күндерергә тырыштытырышты да кул селтәде – аннан арынуны хуп тапты.* З.Мурсиев

**ХУПЛА́У** *ф.* 1) Кемнең дә булса фикерен, эшен, үз-үзен тотышын һ.б.ш.ны кулай, дөрес дип табу, кабул итү, урынлы дип исәпләү, мәслихәт күрү, аңа карата уңай фикердә булу. *Әллә шуңа, әллә әнисенең бик үк хупламавын сизенеп, Исхак Имәнле урамына барып йөрүен сирәгәйтте.* А.Гыйләҗев. *Җитәкче кеше аның алга омтылышларын күреп ассызыклап торды, коллегалары ихлас хуплады, куанды Фәзилә өчен.* Г.Мирһади

2) Нәрсә белән дә булса килешү, риза булу. *Ул иптәшләре аның бу ниятен хуплап каршы алырлар дип уйлаган иде.* Г.Әпсәләмов. *Әгәр бу фикерләремне хупласа – шатлана, сикеренә, аяк арамда бөтерелә.* А.Хәсәнов

**Хуплап алу** Берара, кыска вакыт хуплау. *Аның бу гамәлен шыгрым тулы зал хуплап алды.* К.Сатиев. *Аны: «Җырла, җырла...» – дигән тынак, басынкы тавышлар хуплап алды.* Г.Гыйльманов

**Хуплап бетерү** Тулысынча хуплау, барысын да хуплау. *Үлчәүнең ике ташы шикелле итеп күз алдына китерсәк, димәк... димәк, безнең гыйлем өлкәсендәге гамәлләребезне хуплап бетерми ул.* В.Имамов

**Хуплап җибәрү** Бераз, берникадәр хуплау. *Әй без хуплап та җибәрсәк, башы түшәмгә тия.* А.Вергазов

**Хуплап кую** Кинәт хуплау, бер тапкыр хуплау. *Ак күлмәкле, ап-ак чәчле Кол Гали хуплап куйды: – Киләчәк буыннар бәхете хакына изге яуга кердек, болгарларым!..* В. Имамов

**Хуплап тору** Даими рәвештә, гел хуплау. *Председатель Мөбин абый башка чакта минем укуыма каршы түгел, киресенчә: «Укы, энем! Укысаң, әрәм булмассың», – дип хуплап тора иде.* В.Нуруллин. *Маһирәнең дә балага чат ябышуы, әнисенең аны һаман хуплап торуы да нык шикләндерә башлады.* Г.Галиева

**Хуплый башлау** Хупларга тотыну. *Барысы да берьюлы нәрсәнедер хуплый башласа һәм бер-бер артлы котлау телеграммалары яудырсалар, шикләнмичә әйтергә мөмкин: димәк, рәхәт торгынлык башланып килә...* Р.Хәкимов. *Баштарак аларны тәнкыйтьләсә, инде чирәм җирләрне үзләштерү башлангач, андыйларны ул мактый, хуплый башлады.* Фән һәм тел

**Хуплый бирү** Бернигә карамыйча хуплау. *Ул аларның фикерләрен һәрьяклап хуплый бирде.* Ф.Яхин

**Хуплый төшү** Беркадәр, бераз хуплау. *Һәм шунда берничә автор башлангыч чор иҗатымны хуплый төшәләр.* И.Вәлиулла

**ХУР** I *и. гар.* 1) Оҗмах кызы; ислам динендә җәннәткә эләккән ир кешенең күңелен күрә торган мәңге яшь гүзәл кыз. *Мин хәзер оҗмах түрендә – бер матур хур иркәли ---.* Г.Тукай. *Оҗ-*

*махларда үскән хур кирәкми, Күз алларымда ла син булгач.* А.Хәсәнов

2) *күч.* Кара күзле, матур йөзле гүзәл кыз; искиткеч чибәр кыз. *Сөйкемле хур*

◊ **Хур кызы** 1) *к.* **хур** I. *Без дөньяда менә шушындый җир кызларын кочабыз, ахирәттә, җәннәттә хур кызларын кочар өчен.* Г.Камал. *Әйтерсең лә Кавказ егете җир кызына – тире һәм сөяктән укмашкан гади җир кызына түгел, буй җитмәс ерактагы, хыялдагы оҗмах кызы, хур кызына мәхәббәтен җырлый...* Д.Булатова; 2) *күч.* Бик чибәр кыз. *Әнә Флүс төшендә хур кызын кочагында эретеп ята.* Т.Галиуллин. *Хур кызы көтмичә, булганына шөкер итеп кенә яши белгән иргә назлы хатын, туклыклы аш, туйдырмас хезмәттән кала бәхетле булу өчен тагын ни кирәк соң?* В.Имамов

**ХУР** II *с. фар.* **1.** Начар, яман, кадерсез, түбән, игътибарсыз. --- *бу каһәрле кавемнең өстенә атылып яткан бу яшен кебек уклар, вә бу җәһәннәм кебек ашаучы утлар әллә безне бу сәфил (хур кеше) вә бәхетсез хәлемездән коткару өчен микән?* Г.Бубый. --- *затсыз, хур кешеләр җөмләсеннән булма.* К.Насыйри

**2.** *и. мәгъ.* 1) Түбәнлек, кимсетү. *Гыйлемлек – нур, наданлык – хур.* Мәкаль. *Кысса да синдә фәкыйрьлекләр, ятимлекләр мине, Изсә дә үз ишләремнән хур вә кимлекләр мине, – Үтте инде ул заманнар, очтылар шул кош кеби.* Г.Тукай

2) Кимсетелгән кеше, башкалар алдында хурлыкка калучы, билгеле сыйфатлары, белеме, эш-гамәле һ.б. белән башкалардан түбән, ким булган кеше; түбән кеше. --- *икенче берәүләр, каралар – хурлар, кимнәр – үзләренең бик нык сөенгәнлекләрен белдереп, елмаеп, читтән генә, юл буеннан гына карап калдылар.* Н.Фәттах. *Хурларны хурлама, имеш, Зурларны да мактама...* Ф.Җамалетдинова

3) Мәсхәрә, көлке. *Уку – күңел нуры, Укымый калган – кеше хуры.* Мәкаль. *Тормышта адәм хурына Калуларың шул була.* Ф.Дәүләтбаев

◊ **Хур булу** Оятка калу, мәсхәрәгә калу, рисвай булу. *Укыган кеше кайда да хур булмас.* М.Гафури. *Без, хатыннар, хур булдык, дип торабыз, Бәрбәрия әбинең, авыр туфрагы җиңел булсын, кеше яманлый торган гадәте бар иде.* Г.Әпсәләмов. **Хур калу** *к.* **хурлыкка калу**. *Килмешәк шунысын да аңлый башлый: хур калганчы, тотылып кыйналганчы, мондый юл белән эш итү файдалырак та, кызыклырак та.* К.Җәмит. *Нургаянның сарык урлавын исбатлый алмасалар, үзләре хур калачак.* З.Мурсиев. **Хур күрү** Начар, түбән дип уйлау, кимсетү, түбәнсетү, яратмау. *Инде, и падишаһ, шәригатьне хур күрмә, Кыямәт көнендә гадел падишаһлар гөруһыннан булырсың вә хатын сүзенә күп игътибар бирмә, аларда мәкер вә хәйлә күп булыр.* К.Насыйри. *Мин бик хур күргән Сукыр тычкан миңа ана нәсыйхәте кеби яхшы үгет бирде.* Г.Тукай

**ХУРИ** *и. гар. к.* **хур кызы**. *Кырык ел элек синең каршыңда хури идем, фәрештә идем, имеш...* Ш.Камал. *Бара анда бер төркем – хури гүя, Бу кызларны күрүгә – бәгырь көя.* Ф.Яхин

**ХУ́Р ИТҮ** *ф.* 1) Мыскыллау, мәсхәрә итү, кимсетү; хурлау. *Кайвакытта ул хата бөтен нәсел-нәсәбеңне хур итәрлек, гомергә онытылмаслык бер кара тап булып кала.* М.Мәһдиев. *Ирне зур иткән дә – хатын, хур иткән дә – хатын, дип бик дөрес әйткән борынгылар.* В.Нуруллин

2) Кыз кешене көчләп мәсхәрәләү. *Хур ителерлек кызым юк, яшисен яшәгән, ашыйсын ашаган.* К.Тинчурин. *Бар ир затын чура – кол итте. Хатын-кызны көчләп хур итте.* М.Җәлил

**ХУРИЯ** *и. гар. иск. к.* **хур кызы**. *Тулган ай, хурия образлары, Г.Кандалый тарафыннан тиңләштерелгәндә, бергә кушылып та китәләр.* Р.Харрасова

**ХУРЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **хурлау**. *Хурланган күңеле һич тә ышанырга теләмәде, ләкин булган нәрсә, аның килмәве һәм аяусыз акыл шул турыда сөйләде.* Н.Фәттах. *Бу китапның буеннан буена ана телебез шулкадәр кимсетелгән, хурланган, бу тәрҗемәдән беркем дә берни дә аңламаячак.* Мәдәни җомга

2) Гарьләнү, кимсенү, үзен кимсетелгән итеп сизү. *Күпме кимсенде, күпме хурланды, малай-шалайдан күпме әр-хур ишетте, күпме кыйналды ул шуның аркасында!* М.Маликова. *Бер туй ясарлык рәтең булмагач, ничек хурланмыйча өйләнергә?* З.Мәхмүди

3) Оялу, уңайсызлану. *Аның ире белән ничек җәфаланулары турында, иренең шундый булуына ничек газаплануы, борчылуы, кешедән хурлануы, гарьләнүе турында – барысын да сөйләде бу ханымга.* М.Вәли-Барҗылы. *Ә бу эштән ул бик хурлана иде: биш ел интегеп-интегеп институтта укы да себерке күтәреп урамга чык, имеш.* Н.Гыйматдинова

4) сир. Җирәнү. *Таратыгыз мескеннәргә, мохтаҗларга, бу сөякле куллардан хурланмагыз!* К.Тинчурин

**ХУРЛАТУ** *ф. йокл. юн. к.* **хурлау**. *Күп агайлар, тезләренә терсәкләрен салып, башларын түбән игәннәр, гүя алар фермалары өчен дә, Нургали өчен дә бик гарьләнәләр һәм Нургалигә, үзен дә, ферманы да шул күркәдән хурлаткан өчен, ачулары килеп, күтәрелеп карыйсылары килмичә утыралар иде.* Ә.Еники. *Артыңнан килеп йөргән егетне кемнең хурлатасы килсен.* Л.Ихсанова

**ХУРЛА́У** *ф.* 1) Тиргәү, сүгү, ачулану, әрләү, сүз белән кимсетү. *Әшәке сүз әйтеп, кайсыгызны булса хурладыкмы? Г.Кутуй. Бу шагыйрь абзый һәммәсен дә хурлый, димә, сеңел.* Н.Гыйматдинова

2) Кемне дә булса начар дип, гаепләп, яманлап сөйләү, кара ягу, яман атын сату. *Шунысы сәер: боларның кайсын тыңласаң да, үзенә җылы түбә, ризык биргән йортны, анда эшләүчеләрне хурлый, әниләрен хокукларыннан мәхрүм итүчеләрне гаепли.* Р.Габделхакова. *Ират һаман әле хөкүмәтне сүгә, байларны хурлый, зарланып бушамый, баскан урынында таптана.* К.Кара

3) Мыскыл итү, мәсхәрәләү. *«Менә бу кеше туебызны туктатып иконабызны хурлады», – дип, Әбүбәкерне судка биргәннәр.* Ф.Гарипова. *Үзен шулай тупас төстә кире каккан, хурлаган өчен Рәфистән үч алу турында ул төне буе план корды.* А.Вергазов

4) Көчләп мәсхәрәләү. *Соңыннан шул беленде: бертуган сеңлесен рус егете хурлаган булган икән.* М.Әмирханов. *Ә кызымны хурлаган өчен бернинди дә җәза юк!* Х.Ибраһим

**Хурлап алу** Бераз гына хурлау. *Җырлап ала чегән, хурлап ала Атыңны һәм нәсел-затыңны...* Ф.Гыйззәтуллина. *Урынбасар миңа Гөлчирә апаны хурлап алырга да онытмады.* Безнең гәҗит

**Хурлап бетерү** Бик нык хурлау, каты хурлау. *Аннары, дары кебек кабынып, әниең ташланды, әлләниләр әйтеп хурлап бетерде.* С.Сабиров. *Фетнә чыгарып, ислам динен хурлап бетерергә тырыштылар.* Өмет

**Хурлап йөрү** Озак вакыт дәвамында хурлау, гел, даими хурлау. *Мин биргән дәресләрне әле берәүнең дә хурлап йөргәне юк.* Э.Яһудин. *Концертлар вакытында юмористик чыгышларымда*

*рәхәтләнеп көлеп утыралар, шау-гөр килеп кул чабалар икән, соңыннан мактап я хурлап йөриләр икән – бу минем өчен иң зур бүләк.* М.Кәбиров

**Хурлап ташлау** *сөйл.* Ялгышлык яки кызулык белән хурлау. *Ә Мөслах карт исә болай уйлады: «Җирләрен ялгыш хурлап ташладым, телемне корт чаккыры».* Ф.Яруллин. *Ояны артык хурлап ташлады, ярамаслык түгел әле ул.* М.Хуҗин

**Хурлап тору** Хәзерге вакытта хурлау, шактый вакыт хурлау; даими хурлау. *Кешеләрне гел хурлап торып кына үстереп булмый, мактап алырга да тиеш без.* Г.Афзал. *Гаепле мин: гел аны хурлап тордым, Барын яшереп синнән, югын арттырдым... Көткәнгәме ирештем?..* Р.Гаташ

**Хурлап узу** *к.* **хурлап үтү**. *Җыелышта ул безнең сыйныфны да хурлап узган, диләр.* Р.Вәлиева

**Хурлап үтү** Сүз арасында, башкалар белән беррәттән хурлау. *Безнең оешма эшчәнлеген дә хурлап үткән яңа җитәкче.* И.Нуруллин

**ХУРЛАШУ** *ф. урт. юн. к.* **хурлау**. *Аның авыз читендәге елмаюга охшаган чырае кеше белән очрашканда да, аерылышканда да, макташканда да, хурлашканда да шулай үзгәрешсез калганын белә Тәлгать.* А.Хәлим. *Мәктәпкә баргандагы үзара үчекләшүләр, хурлашулар тәнәфес вакытларында еш кына урамга чыгып таш атуга әйләнеп китә.* Р.Зарипов

**Хурлаша башлау** Хурлашырга тотыну. *Көрешүгә үк бер-берсен хурлаша башлый икән алар.* Әкият

**Хурлашып алу** Тиз генә, кыска вакыт аралыгында хурлашу. *Шул арада хурлашып алырга да өлгергәннәрме инде?!* Р.Вәлиев

**Хурлашып китү** Нindидер сәбәптән кинәт хурлаша башлау

**Хурлашып тору** Әле, күз алдында хурлашу; һәрвакыт яки әледән-әле хурлашу. *Хурлашып торуларын үз күзләрем белән күрмәсәм ышанмас та идем, халык бөтенләй башкача сөйли бит әнә.* Г.Галиев

**ХУРЛЫК** *и.* 1) Мәсхәрә, изелү, кимсетелү хәле. *Безнең халыкның тырышу юнәлеше – башкага кан-нәсел бирүе хурлык кына да түгел (моңа сүз табып бетереп булмый), бу манкортлык кына да түгел, бу мәгънәсезлек кенә дә түгел, моны мисезлек дип кенә атап буладыр инде.* Б.Рәхимова. *Ул, бу хурлыкларга түзә алмыйча, гаиләсен алып, читкә – Урал якларына чыгып китә...* М.Яһудин

2) Гарьлек. *Шуның хурлыгыннан, куркуын да онытып, хәтсез генә басып торды.* М.Кәбиров. *Бу һич тә хурлык яшьләре, кайгы яшьләре түгел, сөенү яшьләре иде.* Д.Каюмова

3) Түбәнлек, кимлек. *[Сәринә:] Сатир патшаның улына кияүгә чыгып, мин үз халкымны талаудан, хурлыктан коткарам дип белдем, уйладым.* Н.Фәттах. *Алар үзләре үскән вакытта армиягә алынмау хурлык саналганга, бераз күңелен нидер кимереп куйса да, инде халык арасында йөргән төрле сүзләрне ишетеп, алынмавына сөенгән сымак та булды әле.* Г.Бәйрәмова

4) Кимсенерлек, оялырлык, башкалардан уңайсызланырлык гамәл; оят. *Тулмаган савыт, чиләк белән урманнан кайту безнең авылда зур бер хурлык санала иде.* М.Мәһдиев. *Кеше арасына чыккач кына амин тотуны да, нишләптер, хурлыкка саный башладыгыз түлке.* А.Әхмәтгалиева

◊ **Хурлыкка калу** Оятлы булу, мәсхәрәгә калу, хур булу, рисвай булу. *Моннан ары да көтеп тору – чамадан тыш түбәнчелеккә төшү, Роза алдында гына түгел, бөтен авыл халкы алдында хурлыкка калу булыр шикелле тоелды Фәләхкә.* В.Нуруллин. *Галия, кара күзләреннән зәһәр чәчеп: – Мин барыбер Җәббарны сиңа бирмим, аның белән төннәр уздырып хурлыкка калма! – диде һәм сумкасындагы кәнфитләрне кибет өстәленә сибеп җибәрде.* Н.Гыйматдинова. **Хурлыкка төшерү** Кимсетү, гарьләндерү; хур итү. **Хурлыкка төшү** *к.* **хурлыкка калу**. *Син бит мине хурлыкка төшерәсең, оятка калдырасың.* Ш.Әхмәдиев. *Рәтле җәмгыятьтә андый ялгыз карчыкларга, аларны мондый хурлыкка төшермичә, печәнне китереп бирәләр яисә кергән сатып алырлык пенсиясен түлиләр.* Т.Галиуллин

**ХУРЛЫКЛЫ** *с.* **1.** Кимсетә, түбәнсетә торган, намуска тия торган, мәсхәрәле, оят. *Иртәгә үк бөтен кеше шушы хурлыклы исем белән Тәнзиләне атый башласа*? А.Гыйләҗев. *Сабыеңа «зинадан туган» дигән хурлыклы тамга салдың.* Г.Галиева

**2.** *рәв. мәгъ.* Хурлык белән, хур ителеп, мәсхәрә белән. – *Тәҗрибәм бар беркадәр, – диде, акрын гына, бүгенге хурлыклы тукмалудан соң үз-үзенә ышанычын югалта барган Сәнгат.* Т.Галиуллин. *Исән калган монголлар, кайтып, Чыңгыз ханга беренче тапкыр хурлыклы рәвештә җиңелүләрен хәбәр иткәннәр.* Р.Ахунҗанова

**ХУРСЫНУ** *ф.* Хурлану. *Шул Сәйфелмөлекләр белән бер юлда йөрергә хурсынам...* А.Гыйләҗев. *Фәннан Барышевның төрпә-тупас соравында Фарук белән Фәүрияне мәсхәрәләү дә, аларның бер-берсен белешүеннән хурсынугарьләнү дә бар иде.* М.Хуҗин

**Хурсынып бетү** Бик нык хурсыну. *Үзенең мондый киемнәреннән ул хурсынып бетте, тик беркемгә дә сиздермәскә тырышты, башкалар кебек елмайды, көлде.* Мәйдан

**Хурсынып йөрү** Озак вакыт дәвамында хурсыну, гел, даими хурсыну

**Хурсынып кую** Бер тапкыр хурсыну. *Ул хәлләрне искә төшергән саен хурсынып куя иде кыз.* Р.Вәлиев

**ХУТ** I *и. рус сөйл.* 1) Юл, йөреш, барыш. *Хут белән уйнаган шәйгә ут белән дә уйналды.* Р.Мингалим. *Һаҗирә, юк йомышын бар итеп, чоланга чыгып керергә кузгалды да шул хут белән Мулланурларга йөгерде.* Г.Бәйрәмова

2) Тизлек. *Имеш, таудан хут белән менсен өчен, матайның «газын» – ат колагын борырга кирәк.* З.Хөснияр. *Әнә шулай итеп, ул елны «Трактор»ның хутын арттырырга тырышуым гел бушка китте.* В.Нуруллин

3) Егәрлек, физик көч, энергия. *Чөнки үзенең хуты – егәрлеге бик чамалы.* В.Имамов. *Тибәргә, аннан җиңәргә Бер хутлары юк икән...* Л.Шәех

4) Кемнең дә булса үзенә уңайлы булган вакыт, юл, транспорт чарасы һ.б.ш. үзе тапкан мөмкинлек, чара, җай. *Үз хутыбыз белән бардык.* Р.Юныс. *Калганнарыгызга үз хутыгыз белән барырга туры килер.* Л.Лерон

5) Мөмкинлек. *Минем төнлә утырасы килә, даһи шигырьләр язасы килә – хут юк.* Р.Фәйзуллин. *Кире кайтып китәрлек хут юк.* Д.Булатова

6) *күч.* Җай, көй. *Дөнья ансыз да үз хутына тәгәри икән шул, тормыш дәвам итә: көннәр – төнне күрергә, төннәр көнгә сәлам бирергә ашыга икән.* Г.Мирһади

◊ **Хут алу** Тизлеген арттыру, тизләнү, көчәю. *Бераз көчәнгәч, автобус хут алды, отыры бер көйгә генә чаба башлады.* В.Нуруллин. *Җир өстенең көпшәклеге хут алырга ирек бирми, йолкып-йолкып тартканда гына,*

*көпчәкләрнең кыймылдаганы сизелә.* К.Кәримов; 2) Көч алу, хәл алу, уңышлы башлап (башланып) китү. *Шуннан хут алып сөйләп китте Беренче.* Т.Нәҗмиев. *Уйлап-уйлап куям да, бер дә хут алып китәр төсле күренми кебек сымак тоела күмхуҗ дигәннәре.* Ф.Сафин. **Хут бетү** Юл калмау, җай калмау, мөмкинлекләр чикләнү, көн бетү. *Кырым татары Кәрим Җаманаклының вафатыннан соң, анда безнең як кешесенә хут бетте.* Т.Галиуллин. **Хут бирү** *к.* **юл кую**. *М.Галәүнең «Болганчык еллар» романына Казанда хут бирмиләр.* М.Мәһдиев. *Фәлиновның энесе эшсез әнә, агроном кисәгә күптән хуҗалык сорый иде, нишләптер, Әмирулла гына хут бирмәде.* Н.Гыйматдинова. **Хутка җибәрү** 1) Җайлап җибәрү, көйләү, ремонтлау, ясау; эшләтә, куллана башлау. *«Хәзер машина тәгәрмәчен хутка җибәрәбез аны», – диде дә җиң сызганып эшкә кереште ---.* Н.Гамбәр. *Насосны хутка җибәреп, бишенче катка носилка белән измә ташу мәшәкатеннән котылгач, кызларның кәеф бөтенләй күтәрелде, көлешкән, шаярышкан авазлар да ешрак ишетелә башлады, кайберәүләре җырлап ук җибәрделәр.* Р.Вәлиев; 2) Кулланy, файдалану. *Берсе, исереграге, йодрыгын ук хутка җибәрә башлаган иде, Харис берне кундырып алды...* С.Сабиров. *Садри икенчеләй стаканны хутка җибәргәннән соң, тәрәч балыгының соңгы кисәкләрен чүпли иде инде.* К.Кара. **Хутка китү** 1) Җайлану, уңайлану. *Болай булса, эшләр хутка китә бит безнең!* А.Вергазов. *Гали яхшы башлады, димәк, болай барса, эш пулный хутка китәчәк.* Ф.Хәбибуллин; 2) Эшкә ярый башлау, кулланыла башлау, кирәге чыгу. *Җиһанша абзасының ятим яткан эш кораллары хутка китте.* А.Гыйләҗев. *Теш пастасы, кырынганнан соң сөртә торган лосьоннар хутка китте, хатын-кызлар авыз суларын корытып та алырга акча кызганган, берсе-берсе егерме-егерме бишәр тәңкә торган кыйммәтле хушбуйларны да калдырмадык.* Н.Әхмәдиев. **Хутка салу** *к.* **хутка җибәрү**. *Шул гигантны хутка салып җибәрү белән, бөтен гигант кузгала.* *Г.Камал.* **Хут кую** *к.* **юл кую**. *Кызган чакта кешегә хут куясы җирдә аркылы төшеп торасың.* А.Хәсәнов

**ХУТ** II *и. гар. иск.* 1) *к.* **кит**. --- *хут балык кебек хайваннар авызына төшеп, ничә-ничә миллион тамчылары юк буладыр.* К.Насыйри. --- *хәзрәте Юнысның хут балыгы карынында исән калуы, хәзрәте Гайсәнең үлгәннәрне терелтүе, пакизә Мәрьямнең балага узуы һ.б. да могҗиза исәпләнә.* А.Тимергалин

2) Йолдызлык тамгалары буенча 22 февральдән 22 март арасындагы вакыт һәм шул вакытка караган ай исеме; март. *«Ут ае – хут ае», – ди мартны керәшен. Чынлап та бу бәя Бик хаклы, күрәсең.* К.Булатова. *Ай исеме буларак «хут» атамасы безнең халык сынамышларында еш очрый: «Хут туды – ут туды», «Хут көне – ут көне», «Хут керде – хатыннарга ут керде» һ.б.* Н.Максимов

3) Йолдызлык атамасы; Балыклар. *Бу – кояшның Хут (Балык) йолдызлыгыннан үтү вакыты.* Н.Максимов

◊ **Хут суыгы** Февраль-март айларындагы салкын көннәр, кышның соңгы суык көннәре. *Шул гына эчен пошырса пошыра. Анда сугым чорын үткәреп, йөк-йөк тире-яры җыеп, хут суыклары үткәч, Оренбурга кайтып керер ул, боерган булса.* Ф.Сафин

**ХУТКА** *бәйл.* Нәрсәдер эшләгән вакытта, шул җайга, уңайга, рәттән. *Чыккан хутка ук миңа указка белән берне сыптырды.* А.Хәсәнов. *Сикергән хутка башы белән чоңгыл төбендәге ләмгә кадалган Марсель.* К.Кәримов

**ХУТЛАНУ** *ф.* 1) Җайлану, рәтләнү, юлына төшү. *Хутланып китә алырлар микән дип шикләнебрәк тә йөргән идем.* В.Нуруллин. *Өч мәртәбә өшкергәч, тәки хутланды аяк.* Н.Гыйматдинова

2) Тизләнү. *Машина хутланды*

3) Берәр нәрсә эшләргә яки берәр җиргә барырга җыену, ниятләү, юнәлү. *Башладык, егетләр! Мич чыгарыйк хутлап.* М.Вәлиев. *Мал духтыры, бүген-иртәгә суябыз, хутланасы юк, ди.* Н.Гыйматдинова

**Хутлана башлау** Хутланырга тотыну. *Кунакка барырга хутлана башлады*

**Хутланып бетү** Барысы да хутлану, тулысынча хутлану; хутланган хәлгә килү

**Хутланып китү** Кинәт хутлану. *Эш хутланып китте дигәндә генә, әллә каян тәкә килеп чыга да теге ирне арттан килеп селтәп ыргыта.* Мәзәк. *Матай да хутланып китте.* Аманулла

**ХУТЛАТУ** *ф. төш. юн. к.* **хутлау**. *– Мин әлдә аларны атаганым юк иде, үзегез карагыз, мин кузгалыем, авылның аргы очына барып багыем, бәлки, анда да алучы булыр, – дип, машинасын хутлатып кузгалып китте.* В.Ильясов. *Чапкычларны хутлатыгыз, Юл буйларын чабып йөрсен!* Р.Гарифуллина

**ХУТЛАУ** *ф.* 1) Әзерләү. *Син, ди, минем арттан менәрсең, ди, каеш хутла, без бергә килгәч, каеш белән бәйлә, ди.* Әкият. --- *тавышың түбән очка кадәр ишетелә иде элегрәк. Хәзер дә әле, Аллага шөкер – азан әйтергә хутлаган кебек.* Р.Зәйдулла

2) Тизәю, тизлекне арттыру, кызулану. *Аска таба Чаба-чаба Китәм хутлап – Булмый туктап!* Р.Миңнуллин. *Карт шагыйрьнең (юкса аңа әле илле дә тулмаган була) «эшче темасына» язган «Поезд китте хутлап-хутлап, стансада торды туктап-туктап» дигән юллары, телләргә күчеп, З.Бәширине «шөһрәткә» күмә.* Р.Зәйдулла

3) Җайлау. *Эшләрен хутлады*

**Хутлап җибәрү** Хутланган хәлгә китерү, тиз арада хутлау. *Бер хутлап җибәргәч бит ул су тирмәне әйләнә дә тора, ә без шул арада «тегене» кәгеп чыга торган идек.* А.Алиш

**Хутлый башлау** Хутларга керешү

**Хутлый тору** Даими, һәрвакыт хутлау; хәзерге моментта хутлау; хутланган хәлдә тоту. *Киемнәреңне хутлый тор*

**ХУТЛЫ** *с.* **1.** 1) Уңайлы, җайлы. *Миннән дә хутлырак өйдәшне көндез чыра яндырып эзләсәң дә тапмассың.* Н.Гыйматдинова. *Чанасы шактый хутлы булып чыкты.* Г.Әдһәмова // Шәп. *Иң хутлы санаторийларда ял итәчәкбез!* Ф.Баттал

2) Яхшы йөри торган, югары тизлекле (техника тур.). *Машина көчле һәм хутлы күренә.* Р.Сибат

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Җайлы итеп, уңышлы рәвештә. *Ә болай, статистикага баксаң, милли мәктәпләрне бетерү процессы бик «хутлы» бара икән.* Р.Фәйзуллин. *Кичкә тикле бик хутлы эшли.* М.Кәрим

2) Тиз, зур тизлек белән; үз җае белән. *Егет хутлы барган машинаны кисәк туктатты: «Ә син үзең кем буласың соң?» – дигәндәй, Наил Кадыйровичка таба борылган җиреннән, симез иягeн иңбашына терәп, хәрәкәтсез калды.* К.Кәримов

**ХУ́ТОР** *и. венг.* 1) Авылдан читтә урнашкан, йорт-каралтылары, чәчүлек җире булган аерым крестьян хуҗалыгы. *Газнан абзый гаиләсе Таллык дигән җирдә хутор рәвешендә салынган йортта яши иде.* М.Юныс. *Яңа хутор хуҗасы, Столыпинга таяныч буласы*

*бәндә, үзенең комсыз җанын Ходайга тапшырды.* А.Сәләхетдинов

2) Россиянең көньягында һәм Украина, Дон, Кубаньда – кечкенә авыл. *Хутор дисәң, хәтере калыр – анда бер генә исән йорт та юк иде, фашистлар барысын да яндырып, шартлатып бетергәннәр.* Ш.Мостафин. *Яшиләр бит әле хутор булып Балтыйк буе илләрендә.* Р.Фәйзуллин

**ХУТТА** *хәб.* 1) Җайлы, әйбәт, көйләнгән булу. *Әйе, пенсионерның эш хутта икән: эшләмәсә дә, акчасы килеп тора, ашау – байдан, үлем – Ходайдан, дип, рәхәткә тарып, түшәмгә төкереп ят.* Р.Кәрами. *Агрономның эшләр хутта, Сипкән ашламалар чутта.* Р.Гарифуллина

2) Кулланылышта; модада, ихтыяҗ бар. *Моңарчы баян, аккордеон хутта иде, хәзер пианино өстәлде.* Г.Ахунов. *Хәзер су керү киемнәре хутта инде...* М.Кәбиров

**ХУТТАН** *бәйл.* Уңайдан, юлдан, шул ук вакытта. *Баязитова бөтен күчендә йөгергән хуттан баскыч сыман бер тимергә тотынды һәм аякларын җирдән ычкындырды.* М.Мәһдиев. *Бер хуттан прсидәтелгә дә әләгеп куюы бар.* В.Имамов

**ХУТЫНА** *бәйл. к.* **хутка.** *Бөтен хутына алга таба ыргылып барган гәүдә кинәт ритмнан чыгуга, Гыйззәтуллин, иң беренче эш итеп, кулындагы кастрюлен алга таба очыртты.* М.Мәһдиев. *Гайшә, ерылып китәргә генә торган авызын бар хутына җәеп, егетне үчекләп алды: – Ә без тагын, кузна уйныйсыз, дип торабыз...* Ф.Сафин

**ХУШ** I *с. фар.* **1.** 1) Әйбәт, яхшы, шәп. *Аусаң – тирәк, авырсаң – дус; иң хуш дару.* Ф.Яруллин. *Фәләхов сүзгә әвәс, хуш күңелле кеше булырга охшый иде.* А.Хәлим

2) Матур, ягымлы, күңелгә ошарлык. *Кил, кил, Кыш бабай, Күңелләргә хуш бабай!* Т.Миңнуллин

3) Чиста, саф, яхшы тәэсир итә торган; рәхәт (һава тур.). *Сандугачлар сайрый, агачлар яфракка бөреләнә, нәфис хуш җилләр исәдер.* Г.Әпсәләмов. *Гаҗәп ирер Болгар иле, даим исә хуш җилләре, Анда барган кешеләрнең арулана күңелләре.* Г.Макаров

4) Тәмле, яхшы, уңай тәэсир итә торган, күңелгә ятыш (ис тур.). *Шул бөреләрдән шомырт чәчәгедәй хуш ис бөркелә.* А.Алиш. *Тик анда инде көне буе агач эшеннән арып-талып арыган егетләребез, печәннең хуш исләреннән исереп, шундук йокыга тала торган иде.* К.Миңлебаев

5) Күтәренке, бик әйбәт, шат (кәеф тур.). *Без Фәсил Күрми белән бер, Күңелләр хуш чагында, Очрашкан идек нигәдер «Совет» ресторанында.* Г.Афзал. *Ә тавышы – нәкъ минем Гөлҗамалымныкы кебек хуш тавыш лабаса!* А.Тимергалин

**2.** *рәв. мәгъ. сөйл.* 1) Яхшы мөнәсәбәт белән, ачык йөз белән. *Пароходта тегеләр яшьләргә хуш кабул күрсәтсәләр, эшләрнең тагын да җайланып китүе бик мөмкин икән.* Г.Исхакый. *Кияүне хуш кабул итә күр!* М.Фәйзи

2) Рәхәт, яхшы. *[Кәримҗан:] Чәйне рәхәтләнеп эчәр идек. Сез нинди чәй хуш күрәсез?* А.Гыйләҗев. *Тегеләй тартты, болай – барыбер дә күңеленә хуш күренмәде.* Р.Рахман

**3.** *хәб. функ.* Күтәренке, матур, яхшы, әйбәт, шәп. *Хәрәкәттә ял итә, күңеле хуш.* Ш.Галиев. *Кош булып очты биектә! Һәммәбезнең күңеле хуш!* Р.Фәйзуллин

**4.** *кис. функ.* Сөйләүченең сүзен тыңлауны белдереп, «я, шулай да булсын ди», «яхшы, тыңлыйм, дәвам ит» мәгънәсендә кулланыла. *Хуш, мондый сәгать күпме тора, сезнеңчә?* А.Тимергалин. *Әйдә, әйдә, хуш, тыңлыйм сүзеңне.* А.Гадел

◊ **Хуш киләсез (килдегез)** Сәламләү, каршы алу сүзе. *Хуш киләсез, рәхим итеп утырыгыз, дип, ягымлы елмаеп каршылый.* С.Сабиров. *Ленизаны күрүгә, аның каршына килеп басты да: – Хуш килдегез!* М.Маликова. **Хуш килү (булу, тоелу)** Бик ошау, ярау. *Иске танышның – күңелемә хуш килгән каләмдәшнең – үз яныбызда булуы юлны тагын да кыскартыбрак җибәрде.* К.Миңлебаев. *Искәндәрнең боеккан күңеленә шушы мизгелдә ясалма кунакчыллык та хуш килде.* Р.Вәлиев. **Хуш күрү** Ярату, ошату; уңай кабул итү. *Опера һәм балет театрында куелган музыкаль спектакльләрне дә шулай хуш күрәсезме?* Р.Фәйзуллин. *Без моны кайнаган сөт илә тәм итүне хуш күрәбез.* Ф.Яхин. **Хуш яту** *к.* **хуш килү**. *Синең кылмышың кайберәүләрнең күңеленә хуш ятмастыр.* Н.Гыйматдинова

**ХУШ** II *ы. фар.* Саубуллашу, хушлашу сүзе. *Мин, вагон ишегеннән башымны тыгып, бар көчемә кычкырдым: – Хуш, сау бул, Гөлчирә!* Г.Галиев. *Хушыгыз, хуш, оланнар, ашыгам: кичке намазым кала.* А.Гадел

**ХУШБУЙ** *и. фар.* Ислемай, духи. *Үзеннән беленер-беленмәс кенә хушбуй исе дә килгәләп китә.* Г.Галиева. *Янәшәдә утырган ханымның күлмәге, хушбуе, кичә кибеттә күргән муенса турында сөйләшәләр, машина өчен түләнеп бетмәгән акча турында гәпләшәләр.* А.Әхмәтгалиева

**ХУШБУЙЛА́У** *ф. сөйл.* Хушбуй сөртү. *Гәрәй морза, мәшһүр оперettaдагы җыр көенә сызгырынгалап, кырынып, чистарынып бетте дә, чигә-яңакларын хушбуйлап, --- чәчен рәткә китерергә тотынды.* М.Галәү. *Яңа гына ышкыланган тактадай шома йөзен хушбуйлап та өлгергән.* М.Шаһимәрдән

**Хушбуйлап алу** Тиз арада хушбуйлау. *Юган киемнәрен бераз хушбуйлап та алды әле.* Мәйдан

**Хушбуйлап җибәрү** Бераз хушбуйлау

**Хушбуйлап кую** Хушбуйланган итү, алдан хушбуйлау. *Киемнәрен хушбуйлап куйды*

**Хушбуйлый төшү** Тагын бераз хушбуйлау

**ХЎШ ИТҮ** *ф.* Саубуллашу, хушлашу. *Я, хуш иттек, киттем бүгенгә.* И.Юзеев. *Йөгерә-атлый перронга атылып чыккач, ул, вагон тәрәзәсенә якынаеп, Дәүлиевкә елмаеп кул болгады: – Хуш иттек, кордаш. Күрешербез әле!* Д.Гыйсметдин

**ХУШЛАНДЫРУ** *ф.* 1) Яхшы якка үзгәртү, яхшыга юнәлтү. *Я бер Аллам! Күзләренә нур иңдер, күңелләрен хушландыр.* Н.Гыйматдинова

2) Канәгатьләндерү; күңелне күтәрү, рәхәтлек, ләззәт бирү. *Калган балык ашы белән күңелне хушландыргач, кайтырга чыктылар.* Х.Камалов

3) Хуш исләр чыгару, тәмле исләр чыгару; хушбуй сөртү, хуш исле итү. *Никодим карт каяндыр табып керткән юкә кабыкны ислемай белән хушландырды.* А.Хәлим. *Шулай ук мәетне юар өчен дип куелган суны да хуш исле үсемлек яки хушбуй белән хушландыру кирәк.* Ф.Яхин

**Хушландыра бару** Тагын да күбрәк хушландыру. *Сизәсездер: һаваны бөре, туфрак, дым исе хушландырганнан хушландыра бара.* Г.Васильева

**Хушландыра башлау** Хушландырырга тотыну. --- *тарылар арасында карабодайның ак чәчәкләре җирне каплап, тирә-якны бал исе белән хушландыра башлаган --- чакларда, матур аяз көннәрнең берендә, мин тагы үзебезнең*

*Агыйдел буена – Зәңгәр чишмәгә кайтып төштем.* Г.Ибраһимов

**Хушландырып алу** Бераз, тиз генә хушландыру. *Егетләр сары фанер чемоданнарының тар авызын ачып, аннан чиста күлмәкләрен чыгардылар, «Тройной», «Караново», «Жасмин» кебек одеколоннар белән муеннарын, битләрен хушландырып алдылар.* М.Мәһдиев

**Хушландырып җибәрү** Бераз, берникадәр хушландыру. *Август аендагы яңгырлар бик куркыткан иде, сентябрь урталарында көннәр аязып, күңелләрне тәмам хушландырып җибәрде.* Г.Әпсәләмов. *Бу хисләр, бая аның күңелен хушландырып җибәргән якты хисләргә кушылып, матур, нурлы, изге-илаһи бер халәт барлыкка китерделәр.* Г.Гыйльманов

**Хушландырып килү** Күптәннән, электән үк хушландыру. *Йөз еллар буенча күңелләребезне хушландырып килгән иң мәшһүр җырларның гына булса да тарихларын беләбезме, шуның белән кызыксынабызмы?* Г.Бәширов. --- *һәм ул җырлар, озын гомерле булып, инде ничә буын тыңлаучының күңелен хушландырып килә.* М.Шиһапов

**Хушландырып кую** Хушланган хәлгә китерү. *Ахырдан, битенә хушбуй бөркеп, әнкәйне дә хушландырып куя.* Сөембикә

**Хушландырып тору** Озак вакыт дәвамында хушландыру, һәрвакыт хушландыру. *Ерактан ялтырап, күңелләрне хушландырып торсын, ди Мансур.* Ватаным Татарстан

**Хушландырып чыгу** Тулысынча һәм тиз арада хушландыру. *Эшен бетергәч, Гыйфритнең башын, чыраен ислемай белән хушландырып чыкты.* Р.Батулла

**ХУШЛАНУ** *ф.* Кәефләнү, шатлану, куану, күңел булу, канәгатьләнү. *Унике чынаяк сәйлүн чәе эчкәннән соң тәмам хушланган, зиһене ачылып киткән Сөммия, «марҗа» сүзен бик тиз эләктереп алып, җылы урыныннан җәһәт кенә кузгалды да, саубуллашып та тормыйча, урамга атылды.* Р.Габделхакова. *Аша, хушлан, рәхәтлән.* Ялкын

**Хушлана бару** Торган саен ныграк хушлану. *Син янымда булганга күңел хушлана бара икән.* Р.Вәлиев

**Хушланып алу** Тиз генә, бераз хушлану. *Бакчамның матурлыгы белән бераз гына хушланып алам да тагын эшкә керешәм.* Сөембикә

**Хушланып җитү** Тәмам хушлану. *Күңелләре хушланып җиткән тегеләрнең, җырлый ук башладылар.* М.Вәлиев

**Хушланып йөрү** Шактый вакыт хушлану. *Мәшһүр җырчыларны тыңлап хушланып йөрим әле.* Р.Вәлиева

**Хушланып тору** Гел хушлану, хәзер хушлану. *Ә әлегә фотоларны карап хушлана торыгыз.* Идел

**ХУШЛАШУ** *ф.* Саубуллашу. *Бикбулат, җавап көткән кебек, аңа карапкарап торды да, идарәдәгеләр белән хушлашып, ишеккә юнәлде.* А.Гыйләҗев. *Аның Маһирә белән хушлашуын берәүнең дә күз уңыннан җибәрәсе килмәде.* Г.Галиева

**Хушлаша башлау** Хушлашырга тотыну. *Шушы ишек төбендә ул аның белән хушлаша башлады, араларның мәңгелеккә өзеләсен шул мизгелдә тойды.* М.Маликова. – *Аларны алам да поездга йөгерәм, – дип хушлаша башлады.* Ф.Сафин

**Хушлашып йөрү** Озак хушлашу. *Хәзер менә кияү атнасы, яшьлек белән хушлашып йөрүебез.* Р.Рахман

**Хушлашып калу** Хушлашырга өлгерү. *Бүген-иртәгә фронтка чыгып китәргә торабыз – әллә кире әйләнеп кайтабыз, әллә юк, хушлашып калыргае хатыннар белән, дигән.* З.Зәйнуллин

**Хушлашып тору** Әле, хәзерге моментта хушлашу; билгеле бер вакытка кадәр, икенче очрашуга кадәр хушлашу. *Мәгънәсенә игътибар ителмәгән – шуңа күрәдер кайчак күз алдында Фаил кулын болгап хушлашып тора.* М.Хуҗин. *Ачуланып калма, хушлашып торыйк.* З.Мурсиев

**Хушлашып чыгу** Барысы белән дә берәм-берәм хушлашу, хушлашып бетерү. *Бергә эшләгән хезмәттәшләре, дуслары белән хушлашып чykканнан соң, Җәмил бакчага – Шамил янына ашыкты.* Н.Әхмәдиев. *Үзен озата килүчеләр белән берәм-берәм хушлашып чыккач, Мирсәет вагон баскычына күтәрелде.* Р.Мөхәммәдиев

**ХЫЗЫ́Р БАБАЙ** *и. к.* **Хызыр-Ильяс**. *Гел изгелекләр генә кылучы, мәңге яшәүче Хызыр бабай Ильяс пәйгамбәр камчысы күңел язын башладымы?* М.Хуҗин. *Арабызда үзен артыксынып, юкка чыккан Хызыр бабабыз.* З.Мансуров

**ХЫЗЫР-ИЛЬЯС** *и. дини* Дини мифологиядә тереклек суы эчеп, мәңгелеккә ирешкән, кешеләр алдына ак сакаллы, актан киенгән хәерче, көтүче, мөсафир кыяфәтендә килеп чыга һәм изге күңеллеләргә ярдәм итә торган изге зат (Хызыр пәйгамбәр белән Ильяс пәйгамбәрне бер образда күзаллаудан барлыкка килгән). *Бабайларга да сөйләдем, алар да беравыздан: «Сиңа Хызыр-Ильяс очраган, бәхетле булырсың», – диделәр.* Ә.Афзалова. *Шул чагында ул миңа бөтен инсаниятне сөюче Хызыр-Ильяс кебек күренде.* Р.Батулла

**ХЫЙТЛАНУ** *ф. диал.* Интегү, җәфалану, газаплану; көч сарыф итү, көч кую. *Хыйтланмыйча судан этләй дә тота алмассың.* Мәкаль. *Безнең тикшеренүләребез буенча, мәсәлән, --- хыйтлану, хәситә, чаршын (бал корты «әпәе»), чыны (киләп бавы), шекә (урман карты, гном), шикмә, шомырт, шөпшә сүзләре борынгы болгар теленнән киләләр.* Р.Әхмәтьянов

**ХЫЙХЫЛДА́У** *ф. к.* **хахылдау**. *Кемдер, хатын-кыз чырылдавына аралаштырып, яшь тай кешнәгән төсле итеп, озак хыйхылдады.* К.Нәҗми. *Өйләндеңме – ахылдама, Кияүгә чыктыңмы – уфылдама, Иреңнең кәефе юк чакта хыйхылдама.* Т.Миңнуллин

**Хыйхылдап алу** Аз гына хыйхылдау. – *Туй алдыннан булган кебек дулкынлана башладым хәтта, – дип хыйхылдап алды Хафизов.* З.Фәйзи

**Хыйхылдап кую** Бер яки берничә тапкыр хыйхылдау

**Хыйхылдый башлау** Хыйхылдарга тотыну. *Клуб тирәсендәге яшьләр хыйхылдый башлауга ук, сиздек эшнең нәрсәдә икәнен.* И.Нуруллин

**ХЫЙХЫ́Л-ХЫЙХЫЛ** *иярт.* Ямьсез тавыш чыгарып көлүне белдерә

**ХЫЙХЫ́Л-ХЫЙХЫЛ КИЛҮ** *ф.* Хыйхылдау. *Тубал, хыйхыл-хыйхыл килеп, безне тимер сәнәккә элмәкче... Элми тор әле!* И.Гази

**ХЫРЛА́У** *ф. к.* **гырлау**. *Ул янәшәсендә тигез генә мышнап йоклаган хатынына терсәге белән төртеп куйды: «Хырлама әле чалган сыер кебек!»* Г.Сабитов. *Солдат халкы хырлап, саташып йоклый.* З.Зәйнуллин

**Хырлап алу** Бер мәртәбә хырлау, аз гына хырлау. *Хәбәр китергән чапкын ак күбеккә баткан атын тезгененнән тотып килгәндә, бичара ат кисәк кенә ал аякларына чүгеп, бер якка әйләнеп төште һәм, өзек-өзек бер-ике генә хырлап алды да, абалап өргән эткә пыялалы күзләрен текәп, җан бирде...* М.Шолохов

**Хырлап кую** Бер яки берничә тапкыр хырлау. *Приёмга чират җиткәнне*

*көтеп утыручыларның кайберләре, терсәкләрен тезләренә куеп, башларын түбән иеп, арыган гәүдәләрен ял иттеләр, кайберләре, урындык аркасына сөялеп, башларын стенага терәгән хәлдә йокымсырыйлар, ә кайберләре хәтта утырган җирләреннән хырлап та куялар иде.* Ә.Исхак. *Теге апа йоклый, хәтта азрак кына хырлап та куя.* З.Зәйнуллин

**Хырлый башлау** Хырларга тотыну. *Гариф хырлый башлады.* И.Шиһапов

**ХЫ́Р-ХЫР** *иярт.* Тамак кырганда, карлыккан тавыш белән сөйләшкәндә, йоклаганда бугаздан чыккан тупас тавышны белдерә. *Нотфулла, тамак төбенә кылчык утырган кешедәй, «хыр-хыр-хыр...» дип куйды.* К.Кәримов. *Йоклый хыр-хыр... Акмуен.* Л.Лерон

**ХЫ́Р-ХЫР КИЛҮ** *ф.* Хырлау, хыр-хыр иткән тавыш чыгару. *Тәмәкене күп имүдән хыр-хыр килгән тавыш исә һаман үзенекен тукый: – Тор, каһәреңне!..* З.Фәтхетдинов. *– Җиб-бә-ә-әр, – диде карт, хыр-хыр килеп.* А.Хәлим

**ХЫРЫЛДАВЫК** *с.* Хырылдап чыга торган, карлыккан. *Халитнең хырылдавык тавышы аны сискәндереп җибәрде: – Я, ник сузасың?* Ф.Хөсни. *Төрепкәсен сыбызгы сыман сызгыртып, хырылдавык тавыш чыгарып бер-ике суыргач: – Сүзгә кучсәк тә ярый, – диде, пышылдап.* Ә.Хәкимов

**ХЫРЫЛДА́У** *ф.* Хыр-хыр иткән авазлар чыгару, бугаз тавышы чыгару. *Шәрәфи карт һаман авыр-авыр сулап хырылдый, ара-тирә йомшак кына ыңгыраша да, гүя сөйли: «Әйдә, йоклыйк инде, кызым, мин ялгышканмындыр, йоклыйк, бәпкәм, борчылмыйк, менә мин ничек йоклыйм ---».* Ш.Камал. *Кеше күп: тегеләй дә болай йөриләр, ятканнары хырылдый, бала-чага мыжгый, шап та шоп йөгерә.* Ә.Әминев

**Хырылдап алу** Бер мәртәбә хырылдау; аз гына хырылдау

**Хырылдап җибәрү** Кинәт хырылдау. *Ул кайвакыт йоклау берлән йокламау чигенә барып җиткәндә генә, бер-бер остазбикәнең озын иттереп хырылдап җибәрүе берлән уянды.* Г.Исхакый

**Хырылдап кую** Кинәт бер мәртәбә хырылдау. *Телевизор хырылдап куйды, экранда һаман әле сугышып яткан азиатларның гәүдәләре тасмаларга телгәләнгәндәй булды.* М.Маликова. *– Тамагым, – дип хырылдап куйды авыру, әмма, дөресен әйткәндә, аның хәле әллә ак халаттан, әллә яшь хатыннан балкып торган тынычлыктан яхшырып киткәндәй булды.* В.Исламетдин

**Хырылдый башлау** Хырылдарга тотыну. *Аннары күзләрен йомды, хырылдый башлады, юка гәүдәсе буйлап дулкын йөгереп узды.* А.Гыйләҗев. *Ул көнне Хәмит көн уртасына кадәр һушында иде, кулын Гөлчирәгә сузды да хырылдый башлады һәм тынсыз калды.* Д.Каюмова

**ХЫРЫЛДАШУ** *ф. урт. юн. к.* **хырылдау**. *Суга тончыгучы кешеләрнең кычкырышуын, атларнын хырылдашуын хәзер дә ишетәм кебек.* Р.Хисаметдинов

**Хырылдаша башлау** Хырылдашырга тотыну. *Этләр хырылдаша башлады*

**Хырылдашып тору** Әле, хәзерге вакытта хырылдашу. *Теге ике сугыш чукмары капылт тынып калгандай булдылар, бер-берсенә карашып куркыныч хырылдашып тордылар да аерылыштылар.* Г.Якупова

**ХЫРЫЛТЫ** *и. сир.* Хыр-хыр, гыр-гыр итеп чыккан бугаз тавышы. *Алар, саташып, бугазыннан яман хырылтылар чыгарып, икенче йокы белән йоклый иделәр.* Ш.Камал

**ХЫЯЛ** *и. гар.* 1) Кешенең үзендә булдырырга, үзе ирешергә теләгәнне фантазия нәтиҗәсендә тудырган күзаллавы; киләчәк турындагы уй. *Бу хатны шунда өзеп: «Вәли, мин сине яратам бит, ләкин без синең белән хыялда гына ир һәм хатын булып калырбыз», – дип, хатны аңа борасы килә.* Г.Кутуй. *Хыялый Азат, корыч атында барганда, тылсымлы татлы хыяллар дөньясына кереп чума.* А.Нәҗми

2) Чынбарлыкта кебек итеп күз алдына китерелгән нинди дә булса образларның уйда, күнелдә барлыкка килү процессы. *[Сәхипнең] башы талган, йөрәге суга, хыял артык кызу эшли иде.* Г.Ибраһимов. *Ләкин, Беловега урманнарына керү белән, күз алдына хыялда да тумаган күренешләр килеп басты.* А.Расих

3) *шигъ.* Күңел, күңел түре, хәтер. *Цейлон җирендә йөргәндә, минем хыялымда әнә шул борынгы әкият яңарып китте.* М.Мәһдиев. *Әмма күпчелек вакытта хыялында ук калган ерак ноктага текәлеп, моңаеп утыра.* Г.Гыйльманов

4) Теләк, өмет; омтылыш; алга куелган максат. *Ул аңа үзенә ышанган төсле ышана, шушы яшь һәм гайрәтле кеше күңелендә йөрткән һәм хәзер йөзләгән киртәләрне җиңә-җиңә тормышка ашырырга керешкән хыялларына кушылырга бөтен барлыгы белән әзер.* А.Вергазов. *Тик хыялларын әлегә берәүгә дә, хәтта сердәшенә дә әйтмәде.* А.Әхмәтгалиева

5) Теләк, өмет, омтылыш объекты. *Милли университет хыял гына булып калды.* А.Юнысова. *Аның артыннан Ирек: – Син дә минем хыялым! – дип кычкырып калды һәм үзенә үзе: – Гашыйк булдым мин сиңа, Зәринә, яратам мин сине, – дип өстәде.* А.Мансуров

6) Тормышка, гамәлгә ашмаслык, тормышта булмаган берәр нәрсә турында буш уй; уйдырма. *Җансыз, телсез бу манзараны төш дип тә, хыял-уйдырма дип тә, хатирә дип тә әйтеп булмас иде.* Г.Гыйльманов

**ХЫЯЛЛАНУ** *ф.* 1) Хыялга бирелү, хыялга чуму. *Шулай укый, хыяллана һәм нәрсәдер көтеп, нәрсәдер әзләнә торгач, бервакыт өзелеп-өзелеп гармун уйныйсыларым килә башлады.* Г.Бәширов. *Һәй, рәхәт тә инде ул хыяллана белгән кешегә!* З.Хөснияр

2) Теләү, омтылу. *Ә мин хыялланган яшел басуларга чыгу алай ансат эш түгел икән.* М.Мәһдиев. *Әнә әткәйгә нәселле ат алу өчен һәм каралтыкураны да яңартырга кирәк кадәр акчасын бирде, алма бакчасын да киңәйтергә хыяллана.* Г.Галиева

3) Нәрсәгә дә булса өметләнү, нәрсәне дә булса күз алдына китерү. *– Абый, син хәзер нәрсә ашарыең? – диде ул Бариска, җылы өй турында, булары чыгып торган кайнар бәрәңге турында хыялланып.* Н.Фәттах. *Булмаган нәрсәләр турында юкка хыялланып утырудан авызга тәм иңмәс.* Р.Батулла

4) *сөйл.* Акылына зәгыйфьлек килү, беркадәр акылын җую. *Сагыштан хыяллану дәрәҗәсенә җитү*

**Хыяллана башлау** Хыялланырга тотыну. *Шул ук елларда мин композитор булырга хыяллана башладым.* Р.Харис. *Җиргә өрфиядәй юка, җиңел һәм ап-ак кар төшкәч, кешеләр, аркаларын кызу мичкә терәп, яшел җәйләрдә читтәге балаларына кунакка бару турында хыяллана башлыйлар.* Ф.Җамалетдинова

**Хыялланып йөрү** Озак вакытлар дәвамында хыяллану. *Аның ул чакта, ун классны бетергәч, укытучылар әзерләү курсына барырга хыялланып*

*йөргән чагы булган.* Н.Хәсәнов. *Әллә кайчан инде таңны Казанка буенда каршыларга хыялланып йөри иде, шунда таба атлады.* Г.Рәхим

**Хыялланып карау** Хыялланырга тырышу, хыялланырга омтылу, төрлечә хыяллану. *Нияр генә уйлап, нәрсәләр турында гына хыялланып карамады инде Миңнулла!* В.Нуруллин

**Хыялланып китү** Онытылып, артыгын хыяллану; бик күп хыяллану. *Ләкин докладчы урман эшенең киләчәге турында сөйләгәндә, Газинур шулхәтле хыялланып китте, зал тып-тын утырганда, берүзе кинәттән кул чаба башлады.* Г.Әпсәләмов. *Капыл хыялланып киткән, ахры, менә ачык ишектән, эре-эре атлап, зур сары эт – Фрунзе яки, улы аңлавынча, бөркет килеп керә.* Д.Бүләков

**Хыялланып тору** Әле, хәзерге вакытта хыяллану, һәрвакыт, гел хыяллану. *Аны тәмамлагач, әллә ни хыялланып торырга туры килмәде – эшләдем дә эшләдем.* Р.Миңнуллин. *Әмма хыялланып торырга вакытым юк, гелән уйнап кына йөрмим бит, өйдә үземә йөкләнгән эшләрем дә бар.* Г.Якупова

**Хыялланып утыру** *сөйл. к.* **хыялланып тору**. Бертуктаусыз хыяллану. *Ачлы-туклы килеш шул турыда хыялланып утырган яшь халыкка ни кирәк тагын?* Ш.Шәйдуллин

**ХЫЯЛЛА́У** *ф. сир.* Уйлау, күз алдына китерү. *Шунлыктан ул үзе шикелле зирәк булуына ачык ышанган кызын, бала чагыннан ук, теге каладагы мирза балаларынча тәрбия итәргә хыяллый.* Г.Ибраһимов. *Зиһенле кыз уку турында хыяллый.* Ютазы таңы

**Хыяллап йөрү** Озак вакыт дәвамында хыяллау, һәрвакыт хыяллау. *Зыя ул дөньяны баштанаяк авырулар, пычраклар, гөнаһлар белән тулган бер җәһәннәм сыйфатында хыяллап йөргәнгә, элгәре ул аңа аяк басудан җаны-тәне белән чиркана иде.* Г.Ибраһимов

**Хыяллый башлау** Хыялларга тотыну. *– Әнкәй, мин бер дә китмәс идем дә бит... әнә теге җиде хатыннан бик куркам шул, – дип, тагы күз алдындагы кебек куркынычларны хыяллый башлады.* Шәһри Казан

**ХЫЯЛЫЙ** *с. гар.* **1.** 1) Хыялда туган, чынбарлыкта булмый торган, фантастик, уйдырма; реаль булмаган. *Тик, болай булгачтын, Вәлинең «хыялый ата» булуы ачылыр, миннән көлерләр, дип курка башлавым гына исемдә.* Г.Кутуй. *Алар дамбаның аргы башына чыгалар да, ком өстенә планшет салып, хыялый йортлардагы хыялый квартираларны җиһазлыйлар: төймәгә басып ачыла торган тәрәзәләр...* М.Маликова

2) Хыялланырга ярата торган, хыялга бирелүчән. *Гармун җырлый, гармунга кушылып, хыялый малайның җаны җырлый.* Н.Әхмәдиев. *Хыялый Азат, корыч атында барганда, тылсымлы татлы хыяллар дөньясына кереп чума.* А.Нәҗми

3) Хыялларга бай, хыяллана торган (вакыт тур.). *Күптән түгел генә әнә шул хыялый вакытларны күңелдә кабат яңартырлык, тын гына яткан күңел дәрьясының йөгерек дулкыннарын кузгатырлык бер очрашу булып алды.* Ш.Маннапов. *Бер кичтә, бер мизгелдә аларның хыялый яшьлеге, бәхет канатлары сына: кара көчләр башлаган сугыш, халык өчен бөтенләй кирәксез сугыш, озакламый аларның барын пыран-заран китереп таркатып бетерәчәк.* Р.Батулла

4) Хыяллану халәтен чагылдырган; уйчан (күз карашы, йөз тур.). *Газетадагы бар текстны үзем язам бит, неужели шуны белмәсләр икән дип, хыялый йөз чыгарып сөйләнә ул.* Х.Камалов. *Аэропорт читендәге чирәмлектә хыялый йөзле малай су буена карый-карый каңгылдаучы ялгыз казны куып бара.* В.Вәлиев

5) Серле, тылсымлы; романтик. *Хыялый ай алтын нур сибә.* М.Шиһапов. *Чәчкә бүләк итеп йөрергә хыялый түгел лә инде ул!* Г.Мирһади

6) *сөйл.* Акылга зәгыйфь, исәр. *Я, җитәр, исәркәй, сине кайберәүләр болай да Хыялый Сәлим дип йөртә, ярсыма шулкадәр, күп уйласаң, хыялыйга сабышуың бар, кереп ят инде хәзер, дип эндәште ул үз-үзенә.* С.Поварисов. *Акыл белән яшәгән кеше һәрвакыт ота ул, ә хис колы, хыялый дивана исемен күтәреп, көлкегә кала.* Н.Гыйматдинова

**2.** *и. мәгъ.* Хыялланырга ярата торган, бик еш хыялларга бирелә торган кеше. *Белмиләр бит бу хыялыйлар: күнектерелмәгән атны егерме-утыз минут та бар куәтенә чаптырырга ярамый, андый атның эчтән күкрәге кызып чыга, алган сулышы утын кисәвдәй кайнар була башлый.* В.Имамов. *Хыялыйлар ярдәме белән җир йөзендә күпме могҗизалар туа, зур ачышлар ясала, матурдан-матур киемнәр тегелә, тәмле ризыклар пешерелә.* А.Мансуров

**3.** *рәв. мәгъ.* Хыялларга бирелеп, хыялыйларча. *Үземне эзәрлекләгән, почмакка китереп кыскан, җәза бирү турында хыялый шашынып йөргән адәмгә тап булдым.* Т.Галиуллин. *Нәкъ менә Матурлыкның, Ямьлелекнең үзенчәлекле гәүдәләнешен эзлидер романтик күңел, ерак офыкларга хыялый багып!* И.Вәлиулла

**ХЫЯЛЫЙЛЫК** *и.* 1) Хыялга корылган, тормышка ашмаслык нәрсә; хыял дөньясы. *Хыялыйлык: әкиятлек белән тормыш чынлыгы янәшә торган (бәлки, үрелгән – дөресрәктер) әсәргә «Күл кашлы йөзек» авыррак тоелды да аны үзгәрттем, әлеге янәшәлек исемдә үк сизелә кебек.* М.Хуҗин. *Хикәяләү агышы еш кына хыялыйлык чигенең аръягына менә чыгам, менә чыгам дип чайпалып-чайпалып тора.* Фән һәм тел

2) Хыялга бирелүчәнлек, хыялый булу үзлеге. *Дөресен әйткәндә, хыял, хыялыйлык һәрбер язучы, драматург, шагыйрь иҗатында бар һәм, әлбәттә, булырга тиеш!* Ф.Урманче. *Туган як табигатеннән үз җанына иңгән матурлык, әтисеннән күчкән маһирлык, тырышлык, үҗәтлек һәм хыялыйлык рәссам өчен гомер буена җитәрлек байлыкка әверелә.* Р.Вәлиев

3) Уйчанлык, моңсулык. *– Командировкалы эш яхшы инде, – диде хатын, нindидер хыялыйлык белән.* М.Кәбиров

**ХЫЯНӘТ** *и. гар.* 1) Дошман ягына чыгу, сатылу, илне сату, хаинлек. *Бу кешеләрнең ул илгә хыянәтен, фашистларга сатылуын сизмәде.* Г.Әпсәләмов. *Июль аенда А.А.Власовның илгә хыянәте бөтен фронтка билгеле булды.* Г.Эюпов

2) Нинди дә булса эштә, мөнәсәбәттә (илгә, антка, әманәткә һ.б.) тугрылыксызлык. *Мәскәүдәге хыянәте өчен хан бүген аны астыра ала иде.* Р.Батулла. *Дошман хыянәте кече дәрья, Дусныкы – киң...* Г.Сафин

3) Гаиләгә яки мәхәббәткә тугрысызлык. *Сөешкән җаннарның хыянәте җиңелме?!* А.Гыйләҗев. *Хәмиткә бу сүзләрне тыңлап тору, бигрәк тә Талиянең бер ир дә гафу итә алмаслык хыянәте турында ишетү авыр, иллә дә читен, һай, читен булды.* Г.Галиева

4) Дуслыкка, дусларга тугрысызлык. *Аһ, нинди зур хәсрәт алдавы – хыянәте дусларның!* А.Гадел. *Ә бу йорттагылар кичерә торган ялгызлык сагышы, кайчандыр якын күреп йөргән кешеләренең хыянәте инде хәзер аларга*

*яшьлек елларының, таза-сау чакларының бәхетле мизгелләрен искә төшерергә дә ирек бирми торгандыр...* Ә.Сафиуллин // Башка кешеләргә тугрысызлык. *Ә мелә шул берничә кешенең дә хыянәте йөрәкне яра.* Туган як

5) Ялган, алдау, алдакчылык, намуссызлык. *Ханым-солтаным, тынычлан, бернинди хыянәт юк!* Н.Фәттах. *Явызлыклар, мәкер, хыянәтләр Юк шикелле була дөньяда.* Р.Сафин

**ХЫЯНӘ́Т ИТҮ** 1) Сатылу, илне сату, хаинлек итү. *Ватанга хыянәт итүгә караганда, ул коточкыч үлемне артыграк күргән.* Г.Әпсәләмов. *Миннән теләк шул: нинди генә авыр хәлдә калсаң да ике нәрсәгә хыянәт итмә: аларның берсе – Ватан, икенчесе – Намус.* Ф.Яруллин

2) Гаиләгә, мәхәббәткә тугрылыксыз булу. *Соң үзең уйлап кара инде: сиңа хыянәт итәрлек булсам, башта авыру әниең белән, аннары яшь балам белән чиләнеп, шушы өйдә шушылай ялгыз яшәр идеммени мин?* В.Нуруллин. *Ул шуны белә: мәхәббәткә хыянәт иткән кеше бервакытта да бәхетле була алмый.* Д.Каюмова

3) Ышанычны акламау, кемне дә булса алдау; башкаларны рәнҗетерлек гамәл кылу. *Атасына хыянәт иткән бала игелек күрмәс, диләр.* М.Хәбибуллин. *Димәк, язучы бүгенге көндә үз янәшәсендә иҗат итүче, көрәшүче, тормыш төзүче геройларга хыянәт итте дигән сүз.* М.Вәлиев

4) Кемне яки нәрсәне дә булса башкага алыштыру. *Ә дингә хыянәт итүче динсездән гөнаһлырак булыр.* З.Мурсиев. *Ана теленә хыянәт иттеңме – табаныңны сыйпаган җир, башыңны сыйпаган күк белән үз телең аша бергән бәйләнешне җуясың; шулай итеп, язмыш китабыңны ачканда – бер телдә, япканда икенче телгә күчерелүен Гарештә кичермәсләр, син Күк каргышына дучар булачаксың...* М.Галиев

5) Үзеңнең хыялларыңа, теләкмаксатларыңа тугры булмау, үзең теләгәнчә, уйлаганча түгел, бөтенләй башкача эшләү, принципларга каршы бару, фикерне үзгәртү һ.б. *Әмма ки үземә үзем хыянәт итмәячәкмен!* М.Хуҗин. *Әгәр ул башка һөнәр сайлаган булса, мөгаен, балачак хыялына хыянәт иткән булыр, үзен бәхетле саный да алмас иде.* Т.Нәҗмиев

**ХЫЯНӘ́Т КЫЛУ** *ф. к.* **хыянәт итү**. *Син сөйләгән, син аңлаткан изге Ватаныма һичкайчан һәм һичкайда хыянәт кылмаска ант итәм.* Г.Кутуй. *Шушы мәхәббәтенә хыянәт кылмаска тиеш хатын, башкалар хакында уйлап бәргәләнмәскә тиеш.* Н.Гыйматдинова

**ХЫЯНӘТЛЕ** *с.* 1) Хыянәт иткән, намуссыз, вөҗдансыз. *Әмма хыянәтле кешеләрдән халыклар бизә, аның белән эш кылудан саклана.* Р.Фәхретдин. *Күпме кешеләр хыянәтле җаннар белән бер мендәрдә ята.* А.Гыйләҗев

2) Хыянәттән гыйбарәт, хыянәттән торган; тугрылыклы булмаган. *Хыянәтле вәгъдәләргә мин баш имәм, Бушка гына һичбер нәрсә син бирмәдең; Ул чагында алданганда мин яшь идем.* К.Тинчурин. *Кыямәтле, хыянәтле бу аклык Кирәк булыр микән түрдәгеләргә?* Ф.Гыйззәтуллина

**ХЫЯНӘТСЕЗ** *с.* **1.** 1) Хыянәт итми торган, тугры, намуслы, алдашмый торган. *Ул мине хыянәтсез кешегә санап товар тәкъдим итсен дә, аны шуның өчен тотып бирим икән.* Т.Әйди. *Хыянәтсез дустың, турылыклы юлдашың, менә дигән хатының булыр иде.* М.Хәсәнов

2) Хыянәт, алдашу булмый торган. *Гап-гади, хыянәтсез, гөнаһсыз тормыш төзи алуыма ышанам.* Л.Ихсанова. *Хыянәтсез табыш булмагандай, Тугрылыктан килә югалту.* Ф.Яхин

**2.** *рәв. мәгъ.* Хыянәткә бармыйча, дөреслекне саклап, гаделлек белән, намус белән. *Унике буын баба шушы юланы хыянәтсез үтәп килгән.* Р.Батулла. *Кырык ел буе үзе сайлаган һөнәргә хыянәтсез хезмәт итә һәм генерал-майор дәрәҗәсендә отставкага чыга.* Г.Шәйхи

**ХЫЯНӘТЧЕ** *и.* **1.** 1) Сатлыкҗан, хаин. *Әсирләрне, бигрәк тә безне – татар легионында хезмәт итүчеләрне – илебез дошман, хыянәтче итеп игълан итте.* И.Юзеев. *Ничек кенә газапламасыннар, кызылармиячеләрнең берсе дә фашистларның сорауларына җавап бирми, хыянәтче булудан үлемне артык күрәләр.* З.Мурсиев

2) Мәкер, икейөзлелек белән эш йөртүче. *Ни генә булмасын, үземне хыянәтче дип хис итәм, агач башларына төбәлгән килеш тора бирәм.* А.Хәсәнов. *Хыянәтче белән уртаклык – мескенлек өстендәге мескенлек...* М.Мирза

3) Мәхәббәткә, дуслыкка хыянәт итүче, тугрысызлык күрсәтүче. *Әйтерсең дусты Гөлчирә аңа хыянәт итмәгән дә, Рамил дә хыянәтчене озата китмәгән.* Г.Әдһәм. *Ул Мулланурны хыянәтче дип атаса да, нинди генә сүзләр белән хурларга теләсә дә, аңа яман теләк теләргә күңеле, йөрәге кушмады.* Д.Каюмова

**2.** *с. мәгъ.* Хыянәт иткән, хыянәт итә, сата торган. *Әлеге отряд Әлки, Биләр, Чирмешән, Аксубай, Норлат төбәкләрендә хәрәкәт итә, шушы тирәдәге дисталәгән авылдагы колонизатор һәм хыянәтче алпавытларның утарларын талый, җәзачыларның кечкенә отрядларына каршы тора.* В.Имамов. *Вилдан хыянәтче хатыныннан котылыр, кызы Фәйрүзәсе аның янында калганга сөенер генә иде.* М.Маликова

**ХЫЯНӘТЧЕЛ** *с.* **1.** 1) Сатлык, хаиннәрчә. *Сугыштан кайткач, җиң сызганып тыныч хезмәткә генә тотынган иде, гитлерчы-илбасарларның туган илебезгә хыянәтчел төстә басып кергәнлеге турында кара хәбәр килде.* Ш.Мостафин. *Хәзер менә авылдашларының шундый йомык, хыянәтчел булуларыннан йөрәк әрни.* З.Мурсиев

2) Хыянәт итүчән, хыянәт итә торган. *Барлык егетләр дә шундый хыянәтчел булса, кемгә ышанырга бу дөньяда?* Р.Шәрипова

3) Хыянәтчеләрнеке кебек, хыянәтче кешегә хас; икейөзле. *Илебезгә немец фашистлары хыянәтчел һөҗүмен башлау белән, Гамир Насрый иптәш тә Бөек Ватан сугышына китте.* Т.Гыйззәт. *Шул ук көннәрдә урысларга Рязань кенәзе Олегның, ике якка да ярарга тырышып, хыянәтчел уен алып баруы билгеле була.* С.Шәмси

**2.** *рәв. мәгъ.* Хыянәтчеләрчә, хыянәтчел рәвештә. *Ул булса, бу кадәре дә хыянәтчел кыланмас иде.* Ә.Әминев. *Күзләре хыянәтчел ялтыраган кешедә иман булмас.* З.Мурсиев

**ХЫЯНӘТЧЕЛЕК** *и.* Хыянәт итү гадәте, хаинлек, тугрысызлык. *Хаҗи бәк, Актай вәзир, Энҗе бикәләр конфликтның икенче ягын – түбәнлекне, мәкер, хыянәтчелекне гәүдәләндерәләр.* Ф.Хатипов. *Ләкин аерым гаскәриләр, шул исәптән югары чиннарга ирешкән кайбер командирлар, үзләрен хыянәтчелек белән таныттылар.* К.Гыйззәтов

# Һ

**ҺА** *ы.* 1) Көтелмәгән хәлдән гаҗәпкә калуны белдерү өчен кулланыла. *Исәнме, Анна! Һа! Мин сине татар кызы дип торам бит.* Г.Бәширов. Һа!.. *Онытып җибәргәнмен, унбердә телевизордан футбол башлана бит!* А.Гыймадиев

2) Гаҗәпләнү катыш хуплау, шатлану һ.б.ш.ны белдерү өчен кулланыла. *Яшерен-батырын гына язган тәүге шигырьләребезне бер-беребезгә укыдык. Бер-беребезне: «Һа! Син – бөек!» – дип макташтык.* Зөлфәт. *Үзенә атап иярләнгән айгырны күргәч, соклануын тыя алмыйча, Күчүклан: – Һа-а, миңамы бу елтыр тай? – дип кычкырды.* Р.Батулла

3) Нәрсә белән дә булса риза булмау, ис китмәү, игътибарсызлык һ.б.ш.ны белдерү өчен кулланыла. *Абыйның ачуыннан күзләре усалланып китте: – Һа! Арзан! Аның каруы менә хәзер кыйбатка төште.* Г.Бәширов. *Һа, әйтте сүз! Җәбраил фәрештә өстенә языйммыни мин аны?* М.Галәү. *Һа, бусы инде акылга сыймый!* А.Гыйләҗев

4) Кычкырып тавыш бирү, көлү, мал куу өчен кулланыла. *«Туп-туп кына басып килә...» дип, меңенче тапкыр җырлаулары да, ияген күккә чөеп, «һа-а!..» диеп көлүләре дә, матәм җыелышларында елатырлык итеп хушлашу сүзләре әйтүләре дә күз алдымда тора.* Р.Харис. *– Утырт әле-е-е-е-е-е-е! Һа-а-а-а! – Алар йөгерешкән аланга тиклем кызларны күреп үртәгәндәй түбән генә очып килгән кукурузник --- ары табан очып китте.* Л.Ибраһим-Вәлиди

**ҺАВА** *и. гар.* 1) Кешенең, тере организмнарның сулыш алу мохите: Җир атмосферасында, нигездә азот белән кислородтан гыйбарәт үтәкүренмәле газлар катнашмасы. *Разия, торып, тәрәзәләрне ачып җибәрде. Бүлмәгә саф һава керде.* А.Алиш. *Электр корылмалы кисәкчекләр 100 километрдан алып 1000 километрга кадәр булган биеклектә һава молекулаларын тәэсирләндерәләр, нәтиҗәдә соңгылары яктылык фотоннары чыгара башлыйлар.* А.Тимергалин. *Диңгез һавасы. Һава температурасы. Һава басымы*

2) Җир өстен чолгап алган иркен бушлык; атмосфера. *Һаваларда очкан бөркет кебек, мин ирекле!* Г.Рәхим. *Һава тын.* Н.Яһудин. *Әнә аулак, тын урман яланы өстеннән --- «сверхзвуковой» самолётлар, һава лайнерлары очып торалар.* А.Хәсәнов

3) *сөйл.* Күк, күк йөзе. *Офыклар киң, һава биек һәм суларга рәхәт иде.* В.Нуруллин. *Әгълә-әгълә нигъмәтләрнең Иң татлысы шушыдыр, Һавадагы йолдызларның Иң яктысы шушыдыр.* К.Булатова

4) Атмосфераның, көннең билгеле бер урында билгеле бер вакыт эчендәге хәле, торышы (яңгыр яву, болытлылык, эссе яки салкын булу һ.б.). *Максатлары – кирәк-ярак ташучы транспортны батыру, һава хәлен күзәтүче станцияләрне юк итү.* А.Тимергалин. *Берничә көн инде эссе һава тора.* А.Нәҗми. *Иртәгә ауга чыгасы көнне генә һава бозылып китмәсенме.* М.Әмирханов // Климат, климат шартлары. *Әллә бу җирнең һавасы килешмәде.* Н.Исәнбәт. *Юк, җиңги, Донбассның һавасы бик эссе, миңа кызу ярамый.* Т.Гыйззәт

5) Изафәле тезмәләрдә «атмосферада хәрәкәт итүгә, очуга караган» мәгънәсен белдерә. *Самолёт һава упкынына төшеп алгандагыдай, йөрәгенең бер күтәрелеп, бер түбәнгә тәгәрәп алуы буенча ялгышын сизенде [Сәет]. Мәгәр соң иде.* Т.Галиуллин. *КамАЗ автогигантын һәм Яр Чаллы шәһәрен төзи башлагач та, беренче нәүбәттә һава юлларын ачу, заманча аэропорт булдыру проблемасы килеп туды.* Я.Шәфыйков

6) Изафәле тезмәләрдә «авиациягә караган» мәгънәсен белдерә. *Тавыштан да тиз хәрәкәт иткән истребительләр, секундлар эчендә якынлашып, һава корабы тирәсендә бал кортларыдай әйләнеп оча да башлыйлар.* Р.Ибраһимов. *Әхмәт ерак түгел җирдә тора торган бер һава көймәсенә кулы белән ишарә итте.* Ф.Әмирхан. *Алар тизлекне арттырып һәм һава судносын җиргә таба авыштырып, проблеманы хәл итәргә омтылган.* Шәһри Казан

7) Изафәле тезмәләрдә «авиацион куркыныч, югарыдан ясалган һөҗүм белән бәйле» мәгънәсен белдерә. *Иртәнге тынлыкны бозып, һава тревогасы яңгырый.* Шәһри Казан. *Һава сигналы*

8) Изафәле тезмәләрдә «югарыда, биеклектә, берәр нәрсә өстендә башкарыла торган» мәгънәсен белдерә. *Фигуралы шуучыларның, һава акробатларының чыгышыннан соң, сүзне дәрәҗәле кунаклар алды.* А.Зәкиев. *Мин, булдыра алсам, циркта эшләр идем. Һава гимнасты булып.* А.Гыйләҗев

9) Изафәле тезмәләрдә «кислород белән дәвалануга караган» мәгънәсен белдерә. *Бу тылсымлы һава ваннасын төнге сәгатьләрдә – транспорт хәрәкәте, фабрикалар эшчәнлеге тыйлыккан чакта алу хәерле.* Т.Әйди

10) Изафәле тезмәләрдә «күк йөзен саклауга, хәрби авиациягә караган» мәгънәсен белдерә. *Монда синдәйләр аралаша: соры шинельле солдатлар, офицерлар, һава көчләре, десант, танк, элемтә, эчке эшләр, чик буе гаскәрләре малайлары.* М.Мәһдиев

11) *күч.* Әйләнә-тирәдәге шартлар; вазгыять; әйләнә-тирә, мохит. *Һава кызды, хатыннарның да температурасы арта бара иде, кызган халыкка ялгыш бер очкын төшсә дә, әллә ни булуы ихтимал – дәшмәвең алтын.* А.Гыйләҗев. *Сталин үлеп, кырыс һавалар бераз йомшара башлады.* Р.Мостафин

12) *күч.* Психик халәт, рух. *Күңелләр кайгыдан котылган, Күкрәкләр ирек һавасы белән тулган.* Г.Камал

◊ **Һава алмаштыру** Саф һава кертү, җилләтү (бүлмәне). **Һава алу** Ниндидер бина эченнән саф һавага чыгу. *Беркөнне ул картының көндәгечә: «Мин һава алып керәм, газеталар да аласы бар», – дип китүе белән үк аның артыннан чыкты һәм ерактан гына аны күзәтеп барды.* А.Алиш. **Һава алыштыру** 1) *к.* **һава алыштыру**. *Сыйныф бүлмәсендә балалар утырганда һава алыштырырга уйлап форточка ачсаң, балаларга салкын тиюе бар.* Л.Низамиева; 2) *к.* **һава алу**. *Кичләрен Сабира*

*белән Кәримә шул бакчага истирахәт кылып, һава алыштырып кирәргә чыгалар.* Ф.Яхин; 3) Яшәү, эшләү урынын, мохитне үзгәртү, икенче җиргә күчү. **Һава баганалары** Буш, нигезсез, конкрет булмаган нәрсә турында. *Баһави --- һава баганаларына таянырга белми. Аның таянычы күзгә күренеп торсын.* А.Расих. **Һава белән туену** *ирон.* Ашамыйча тору, бернәрсә дә ашамау. *Ит күргән юкка биш былтыр. Һава белән туенып торган көннәрем...* Ф.Җамалетдинова. *Урманда да һава белән туенып торып булмый.* Т.Галиуллин. **Һава бозу** Арт юлдан сасы ис чыгару, усыру. *Анасы сыер сауганда, сыер һава бозды. «И, оятлы булдым, сыер ояты – минем оят», – дип, барды да базга төшеп утырды.* К.Насыйри. *Торып калган яңа сакчы ыклап ашап чыккан ахрысы, тавыш чыгарып һава бозды да, кабаланмыйча гына, блиндажларны уратып салган сукмак буйлап атлап китте.* З.Зәйнуллин. **Һавага ату** Төзәгән ноктага, мишеньгә тидерә алмау. **Һавага ашу** *к.* **күккә ашу** (*1, 3 мәгъ.*). *Карап торырга мәһабәт буе да юк, җаваплы урыннарда да утырмый, һавага ашкан күктерәр йортлар да төзетми, типтәр әйтмешли, ябай гына бер адәм, сөйләшеп торганда тавышы да чыгар-чыкмас кына кебек.* Ф.Мөслимова. **Һавага күтәрү** *к.* **күккә чөю**. *Газеталар аларны [эш алдынгыларын] һаваларга күтәреп мактау өчен аллы-гөлле сүзләрне кызганмыйлар. Ичмасам, нәниен генә булса да, безнең ишеләргә калдырсалар икән.* С.Рафиков. *Әтием, бер караганда, һавага күтәрә, икенче караганда, бөтенләй хурлап ташлап, җирдә калдыра.* Г.Галиев. **Һавага очу** 1) Көчле шартлаудан, кубарылып, югарыга атылу һәм җимерелү. *Төтен һәм балчыкка уралып, ак фин ныгытмалары һавага оча башлады.* Г.Әпсәләмов; 2) Юкка чыгу, бетү. *Ни әйтсәң дә, газетада язганың һавага очмый, ә ташка басылып кала.* М.Шабаев; 3) Файдасызга, бушка китү; әрәм булу. *Алтмыш-җитмеш миллиард һавага оча икән – очсын!* К.Тинчурин; 4) Хыял белән мавыгып, тормыштан аерылу, тирә-якны күрмәү, исәпкә алмау турында. *– Канатлану – әйбәт нәрсә, ләкин, – профессор ике кулын канат сыман итеп селкеп алды, – һаваларга очып китмәгез.* Г.Әпсәләмов. **Һавага тотылу** *к.* **һавага очу** (*3 мәгъ.*). *– Әйе, бар акча һавага тотыла, – дип уфтанды икенчесе.* Н.Гыйматдинова. **Һавага чыгу** 1) Бина эченнән урамга, тышка чыгу. *Вакытында йоклый, вакытында һавага чыга, уйный, шуңа күрә алма кебек кызарып, матур булып үсә икән.* А.Алиш; 2) *эвф. к.* **тышка чыгу**. *Тоткыннарның ишегалдына һавага чыкканын алар икәү капка төбеннән китмичә көтеп алалар.* З.Зәйнуллин. **Һавага чөю** *к.* **күккә чөю**. *Нәрсәгә бу мактау сүзләре, һавага чөю!* Р.Камал. *Канкардәшләре тарафыннан һаваларга чөелгән Рудольф бу минутларда үзен ерак туган җирендәге талбишектә тирбәлгән бик бәхетле сабый итеп тойды.* Рав.Вәли. **Һавада асылынып калу** 1) Үтәлеп бетмәү, тормышка ашмау яки ашырылмау. *[Кәшһәкнең] әмере дә тузганак мамыгыдай һавада асылынып калды.* М.Әмирханов. *Димәк, беркөн корган уй-планнар да һавада асылынып калачак.* Ф.Садриев; 2) Хәл ителмәү, чишелмәү, чишелеш табалмау; 3) Тиеш булып та нинди дә булса исемлеккә, төркемгә һ.б.ш.га керми калу. **Һавада асылынып тору** *к.* **һавада асылынып калу** *Бигрәк тә милли мәктәп төзү идеясе һавада асылынып тора бирә.* Д.Заһидуллина. **Һавадагы йолдыз** Ирешүе мөмкин булмаган, тормышка ашмаслык нәрсә турында. *Уз дигәнеңә ирештең түгелме, инде һавадагы йолдызга үрелмәкчесең!* М.Хәбибуллин. **Һавадагы кош кебек (шикелле)** Иректә, бәйсез. *Әнисе, без һавадагы кошлар кебек иректә, диде.* А.Хәсәнов. *Миңа нәрсә? Мин әлегә һавадагы кош кебек...* Э.Касыймов. **Һавадагы торна** Бик өметләнгән, арзу ителгән, ләкин кулга төшерү, тормышка ашыру яки үтәү мөмкинлеге аз булган нәрсә турында. *Мәхәббәтеңне югалту – һавадагы торнага алданып кулыңдагы былбылны ычкындыру гына түгел, ул – бәхетеңнән мәңгегә колак кагу һәм көчсезлек галәмәте.* С.Поварисов. **Һавадан акча ясау** Законсыз, харам, җиңел юл белән мал табу хирыслыгы турында. *Булыр-булмас акчага көннәр буе таш чабасыңмы, я булмаса һавадан акча ясап балда-майда йөзәсеңме, өеңдә түшәмгә төкереп ятасыңмы – бу дәүләтне кызыксындырмый.* Н.Шәрифуллин. *Иңе белән буе бер, судагы үрдәк төсле як-якка чайкалып йөри торган Әсмабикә-Асяның һавадан акча ясап баеп беткәне Сәйфигә мәгълүм иде.* Т.Галиуллин. *Аны, каты куллы дәүләт заманында күтәрелгән эшкуарны, наворишларның һавадан акча ясаулары чын мәгънәсендә ярсыта, рәнҗетә иде.* Р.Мирхәйдәров. **Һавадан алып** Бернигә дә таянмыйча, нигезсез рәвештә. *Туры Тукай һавадан алып язмас.* Р.Батулла. *Акыл сата дип уйламагыз: һавадан алып әйтмим.* Сөембикә. **Һавадан көтү** *к.* **һавадан төшкәнне көтү.** *Юк дип һавадан көтеп ятсагыз, бервакытта да булмас.* Т.Гыйззәт. **Һавадан торна санау** Мәгънәсез, кирәксез эш белән шөгыльләнү. *Юк инде, Гриша... Син миңа һавадан торна санарга кушма.* Р.Ишморат. **Һавадан төшкәнне көтү** *к.* **күктән төшкәнне көтү.** *Бөтен нәрсәне хөкүмәттән өмет итеп, һавадан мөлкәт төшкәнне көтеп ятарга ярамый.* Шәһри Казан. **Һавада очып йөрү** Күренмичә генә халык арасында булу, барлыгы сизелеп тору. *Фикер һавада очып йөри икән, димәк, җир йөзендә безнең кебек уйлаучылар да бар.* З.Мәхмүди. **Һавада эленеп калу** *к.* **һавада асылынып калу**. *Ялвару авазы җавапсыз иңрәү булып һавада эленеп калды.* Ш.Шәйдуллин. *Әбез анда юк, Илдар – син дә юк, улым да, мин дә... Без һавада эленеп калганбыз.* Р.Габделхакова. **Һава океаны** Атмосфера, һава (*2 мәгъ.*). *Киңлек, һава океаны игезәкләрне илһамландыра.* Сөембикә. **Һава сугу** *к.* **кояш сугу**, **эссе сугу**. *Дәү әти алсу төстәге чачаклы сөлгесен иңбашына салган була, дәү әни, һава сугудан куркып, сөлгесен башына чалма итеп урый.* Г.Әпсәләмов. **Һавасы төшү** *к.* **кикрик шиңү.** **Һава үбеше** Иреннәрне беркемгә дә тидермичә, берникадәр арадан ясалган үбү хәрәкәте. **Һава яру** 1) Нәрсә дә булса һавада кискен хәрәкәт ясау. *Ә каеш һаман, һава ярып, миңа төшә тора, төшә тора, туктар чамасы да күренми.* З.Мурсиев; 2) Еракка яңгырау, көчле яңгырап ишетелү (тавыш тур.). *Кинәт, тын һаваны ярып, зәңгәр күктә мотор тавышы яңгырый.* Г.Әпсәләмов

**ҺАВА́ АЛАНЫ** *и.* Аэропорт. *Әмма безгә тагы илле минуттан һава аланында булырга кирәк.* Р.Мөхәммәдиев. *Һава аланында очкыч көткәндә, Венера, аның кулын тотып: «Рәхмәт сиңа, профессорым», – диде.* Р.Зәйдулла

**ҺАВАҖ́ЫЛЫТКЫЧ** *и.* Һаваны җылыта торган аппарат. *Һаваҗылыткыч төрләре. Һаваҗылыткычның эшләү принцибы*

**ҺАВАЙӨЗӘР** *и.* Һавадан җиңел очу аппаратларында һавада хәрәкәт итүче,

аэронавтика белән шөгыльләнүче кеше. *Рекордсмен һавайөзәрләр*

**ҺАВА́КУДЫРГЫЧ** *и.* 1) Вентилятор. *[Комбайн кабинасының] Түбә өстенә беркетелгән һавакудыргыч талгын гына җил өрдерә, тик Зариф аны тоймый иде.* М.Хәбибуллин

2) Аш пешерү бүлмәсендә һаваны төтен, ис, бу һ.б.ш.дан арындыру җайланмасы; *русчасы:* **вытяжка**. *Кухняга һәм ваннага һавакудыргыч урнаштырыгыз.* Ватаным Татарстан

**ҺАВАЛАНДЫРУ** *ф.* 1) Бинаны, бүлмәне җилләтү, һавасын алмаштыру. *«Распадская» шахтасы Русиядә соңгы биш елда һаваландыру һәм газны чистарту системалары белән иң яхшы җиһазландырылган шахталарның берсе иде.* А.Кормаш

2) *күч.* Кемне дә булса мактап үсендерү. *Һәммә кешенең кызыгып сөйләгән шул сабак уку мине бераз һаваландырды. Сабак укуның нәрсә икәнене белмәенчә генә, мин шул көнне көтә башладым.* Г.Исхакый

**һаваландырып тору** Гел, һәрвакыт һаваландыру; хәзер, әле һаваландыру

**һаваландырып җибәрү** Кинәт, бераз һаваландыру. *Публиканың лекцияне көтелмәгәнчә җылы кабул итүе Шакир Батырҗановичны һаваландырып җибәрде.* Ш.Бикчурин

**ҺАВАЛАНУ** *ф.* Эреләнү, тәкәбберләнү, масаю, кәпрәю. *Рәфис Шәмсүннең көлемсерәп елтыраган кысык күзләренә, һаваланып өскә чөелгән йомры иягенә, кәнәфидә ярым яткан масаюлы гәүдә торышына күз төшереп, «бәлки, бу егет кисәгеннән пычагым да чыкмас» дип уйлагандыр әле.* А.Вергазов. *Туктамыш Норадын алдында Чыңгыз нәселеннән килгән хан булуы белән һавалана, аны: «Син минем колымсың», – дип мәсхәрәли.* А.Гайнетдинов

**һавалана башлау** Һаваланырга тотыну. *Хәтерлисеңме, Тәңгәрәй, теге вакытта син, шәһәргә китәм, дип һавалана башлагач, мин сиңа нәрсә дигән идем?* Г.Гыйльманов

**һаваланып алу** Бераз, берара һавалану. *Атларны Сәмигулла картның сарай эченә япкач, һаваланып алырга да онытмады үзе.* В.Имамов

**һаваланып җибәрү** Кинәт һавалану. *Безнең группа студентының китабы бит – монда инде шагыйрь түгел, без һаваланып җибәрдек.* М.Хуҗин

**һаваланып йөрү** Озак вакыт һавалану. *Чат Шәрәфинең җебегән Әсмасы да, Яраслауда торфта эшләп кайткач, кем булып шәбәеп, һаваланып йөргән иде.* А.Гыйләҗев. *Быел, шалашымны урманның иң матур аланына корып куйдым, дип һаваланып йөри алмыйсың.* А.Хәсәнов

**һаваланып китү** Соңгы арада һавалану; кинәт һавалану. *Монда мин гаепле булып калганмын, мин гаепле булган очракта, ул шундый һаваланып киткән!..* А.Гыйләҗев

**ҺАВАЛАНУЧАН** *с.* Үзен һавалы, тәкәббер тотучан, масаерга, һаваланырга яратучан. *Менә син нинди икән әле Гөлфинур... Көчсез һәм һаваланучан...* А.Вергазов

**ҺАВАЛА́У** *ф.* Канатларын җәйгән килеш, һавада йөзү (кайбер кошлар тур.). *Әйләнеп кошым кайтмады, һавалап китеп юк булды – Ул ни булыр, әй хуҗам?* Дастан

**ҺАВАЛЫ** *с.* **1.** 1) Билгеле сыйфатка ия һавасы булган; гомумән һавасы булган. *Безнең бүгенге поэзиядә кызлар иҗаты да әнә шулай: тынчу һавалы шәһәрдән табигать кочагына чыгу кебек тәэсир калдыра.* М.Вәли-Барҗылы. *Бу очрашу минутларында Рәйхан үзен саф һавалы нарат урманында сәйран кичкән кебек хис итә, яшьлегенә кайта.* Д.Каюмова

2) *күч.* Үзен бик эре тота торган; масаюлы, тәкәббер. *Ә менә Симеон – чамадан тыш көнчел, хөсетле вә һавалы бәндә.* М.Әмирханов. *Фәһимә тагын элеккеге һавалы Фәһимәгә әйләнде.* Н.Гыйматдинова

**2.** *рәв. мәгъ.* Эре итеп, масаеп, тәкәббер булып. *Ай-һай, һавалы кыланган булалар хәерчеләр, бер дә үзләренә күрә генә түгел.* М.Хәсәнов. *Үзен бик һавалы тоткан бу кунак кодагый да инде онытылып барган Казан апаен исләренә төшерде бугай.* Н.Кәримова

**ҺАВАЛЫК** *и. ялг. к.* **һавалылык**. *– Көтеп-зарыгып торган кешем юк, – диде Вася шул ук һавалык белән.* Н.Акмал. *Әлләкемлек, һавалык, текәлек, мин-кемлек кебек табигый көчеңне, нәфсеңне җиңә алмаудан ул, тәрбия җитенкерәмәүдән.* Ф.Яхин

**ҺАВАЛЫЛЫК** *и.* Һавалы, тәкәббер булу үзлеге, тәкәбберлек. *Ул, бер генә минутка суык вә һавалылыгын азайтып, сәҗдәдән калыккан адәмнәргә бер генә, тик бер генә мәртәбә, сөеп, иркәләп карый да калын катлаулы кара болыт артына кача.* Г.Ибраһимов. *Һәм әнә шуларның барысы өстенә табигать, нәсел тарафыннан бирелгән һавалылык.* М.Мәһдиев

◊ **һавалылыгын шиңдерү** *к.* **кикриген шиңдерү**. *Секретарь белеп тора, бу кыю һәм тәвәккәл И. Кадыйров әйтеп кенә калмаячак, сүзен җиренә җиткерәчәк. Шуңа күрә әлеге сүзләр секретарьның һавалылыгын тиз шиңдерә.* А.Әхмәдуллин

**ҺАВА́ӨРДЕРГЕЧ** *и. тех.* Көчле агымлы яки кысылган һава бирә торган җайланма; *русчасы:* **воздуходувка**. *Шахта эченнән катлаулы системадагы һаваөрдергеч һәм суырткыч торбалар --- үтә.* А.Толстой. *Бирегә көчле насослар, һаваөрдергечләр урнаштырылган.* Әлки хәбәрләре

**ҺАВА́ ПОРТЫ** *и. к.* **һава аланы**. *«Фокус»ым хәлләремне аңлады бугай, бу юлы шигырь юллары тезә башлады: «Аэропорт – һава порты, сагыш йорты... Аэропорт – шатлык йорты, кавышу йорты!»* Л.Лерон

**ҺАВА́САФЛАНДЫРГЫЧ** *и.* Бина эчендәге начар исләрне бетерә, хуш ис тарата торган көнкүреш химиясе чарасы. *Һавасафландыргыч алып сибәргә дә теләгән иде дә таба алмады, шуңа үзенең күз карасы кебек кенә саклап йөргән хушбуен сипте.* М.Кәбиров

**ҺАВА́СУЫТКЫЧ** *и. тех.* Һаваны суыта торган аппарат; *русчасы:* **воздухоохладитель**. *Яңа модельле һавасуыткычлар җитештерү*

**ҺАВА́СЫЕШЛЫК** *и.* Билгеле физик хәлдә туфракның теге яки бу микъдарда һава тотып тора алу мөмкинлеге; *русчасы:* **воздухоёмкость**. *Һавасыешлык күрсәткечләре. Туфракның һавасыешлыгы*

**ҺАВАСЫЗ** *с.* **1.** 1) Һавасы булмаган, һава белән тулмаган. *Җирдә шулай, ә һавасыз бушлыкта (вакуумда) һәм гравитация алты тапкыр чамасы кимрәк булган урында Ай грунты, андагы тузан катлавы үзен ничек тота?* А.Тимергалин. *Анда, җир астында, тончыгып үләрсең, һавасыз, дим.* А.Гадел

2) Һавасы бозылган, тынчу, бөркү; начар һавалы. *Ул [Хәдичә] тын алырга, һавасыз өйдән качкан кеше кеби, атылып, икенче өйгә чыгып китте.* Г.Исхакый. *Мичтәге күмерне болгаткан саен, ургылып, төтен чыкты. Болай да һавасыз өй эчен ис баскандай иде.* Ф.Яхин

**2.** *рәв. мәгъ.* Һавадан башка, һава кулланмыйча. *Кеше җирдә һавасыз*

*яши алмый.* Ш.Галиев. *Ул бит анда һавасыз үсмәс?* Г.Каюмов

**ҺАВАСЫЗЛЫК** *и.* 1) Һава (*1 мәгъ.*) булмау, һавасыз булу хәле. *Кышкы буада калын боз астында калып, һавасызлыктан бәргәләнгән балык халәтендә хис итә ул [Мирсәет] үзен.* Р.Мөхәммәдиев

2) Бөркү, тынчу, начар һава. *Йоклый болыт, итәкләрен Җыймый гына яткан. Озын юллар, һавасызлык Башын аңгырайткан.* Р.Рахман. *Ниһаять, Нәҗипнең түземе бетте, һавасызлыктан йөрәге, башы авырта башлады.* А.Гыйләҗев

**ҺАВА́ҮТКӘРГЕЧ** *и.* Бер урыннан икенче урынга һава үткәрү өчен торба, көпшә һ.б.ш.; *русчасы:* **воздуховод**. *Хезмәт күрсәтелгән бүлмә белән коридорны аерган стена һәм һаваүткәргеч кисешкән урында янгынга каршы клапаннар куелырга тиеш.* Ч.Хаҗиева

**ҺАВА́ЧИСТАРТКЫЧ** *и.* **1.** Бина эчендә һаваны сафландыру һәм атмосфераны яхшырту җайланмасы. *Металл кою заводында, мәсәлән, 350 гә якын һавачистарткыч бар.* Казан утлары

**2.** *с. мәгъ.* Һаваны зарарлы матдәләрдән чистарта торган. *Төтен исе чыкмасын өчен, кафеда гидрофильтрлар куячакмын, әлеге һавачистарткыч җайланма 450 мең сум тора.* Акчарлак

**ҺАВА́ ШАРЫ** *и.* 1) Җылытылган һава яки һавадан җиңел газ белән тутырылган, атмосферада оча алган, башлыча, кәрзинле очу аппараты. *Һава шарында очу*

2) Бүлмәләрне һәм бәйрәмнәрне бизәр өчен кулланыла торган, һава яки җиңел газ белән тутырылган бик юка, күбесенчә латекстан эшләнгән уенчык. *Зурколак урманда һава шары тапкан.* С.Сәүбанова. *Тыны чыккан һава шары сыман бушанып калды ул.* Р.Мөхәммәдиев. *Сезгә тулы ышаныч белән җиткерә алабыз ки, --- чүп кенә проблемаларны һава шары кебек кабартмыйча, ягъни мәсәлән, иң югары ноктасына җиткермичә, --- безнең файдага хәл итәрбез.* Р.Кәрами

**ҺАВЫЛДА́У** *ф. к.* **һаулау**. *Этләр, бик каты һауылдап өрә-өрә, бүрегә ташланганнар.* Әкият. *Күксел томан сарган авыл өстен. Этләр дә өрми инде һавылдап. Зәһәр салкын гына котырына Хуҗа булып бөтен авылга.* Р.Вәлиева

**ҺАВЫЛДАШУ** *ф. урт. юн.* Берберсенә өрү; күпләп өрү; өрешү, һаулашу. *Сөям барын: --- Тыныч кичтә челән тавышларын, Һавылдашып этләр өргәнен.* Ш.Мөдәррис. *Урамда этләр һавылдаша*

**ҺАЙ** *ы.* 1) Соклану, шатлану, көчле гаҗәпләнү хисләрен белдерү өчен кулланыла. *Һай, минем кызым, һай, матурым минем, кер, кер, балам, канатым.* К.Тимбикова. *Һай, балам, кулларың алтын икән!* Р.Батулла

2) Кинәт искә төшкән фикерне әйткәндә кулланыла. *Һай, җәмәгать, мәйданга чыккан Мөнир Рахмаев турында язарга оныткамын бит.* Э.Фатыйхова

3) Үкенү, ачыну, хәсрәтләнү хисләрен белдерү өчен кулланыла. *Һай, ник әйтте икән ул бу сүзләрне!* Г.Әпсәләмов. *Һай, ул ачлык!* Ә.Еники. *Һай, кысылмаган булсачы Фаил!* А.Гыймадиев

4) Шикләнү, борчылу яки курку хисләрен белдерү өчен кулланыла. *Һай, шайтан алгыры, бу юлы ялгышканбыз лабаса!* А.Хәсәнов. *Мирвәлинең мең мәртәбә сынаганы бар: юкка гына керми аңа бу шом. Күңеле сизгер аның, һай сизгер...* Г.Гыйльманов

5) Ачулану хисен, ризасызлыкны белдерү өчен, тиргәү сүзләре янында кулланыла. *[Маһитап:] Һай, оятсыз, нигә юрыйсың?* Г.Ильяси. *Һай дуамал бу Сүбүдәй, һай акылы читән!* В.Имамов. *– Карале, ахирәткәем, Харисың килгәлиме соң? – диде Рәшидә, капка төбендәге эскәмиягә чыгып утыргач. «Харисың...» Һай бу Рәшидәне...* А.Фәләх

6) Ис китмәү яки көлеп, кимсетеп карауны белдерү өчен кулланыла. *Чирләгән икән берәүләр, һай Алла!* А.Гыйләҗев. *Һай, мескен, сиңамы соң инде кояш белән ярышырга.* Г.Рәхим

7) Кемгә дә булса мөрәҗәгать иткәндә яки малларны куганда эндәшү, кычкыру өчен кулланыла. *– Һай, саклан! – дип кычкырды дилбегә тотып килүче.* Г.Әпсәләмов. *Бер-бер артлы сукты атларга тагын ул чарт та чорт. Кычкыра ул: «Һай!» – диеп, атлар да һәм бик нык чаба.* Г.Харис

8) Җырларда иҗек санын тутырыр өчен ялгый торган музыкаль фраза буларак кулланыла. *Тимер челтәр аша, һай, берәү карый, Кай җирләрнең бөркет ләй баласы...* Җыр. *Тауларда, һай, болан баласы, Моннан мәллә кәләш аласы?* А.Хәлим

**ҺАЙДАЛА́У** *ф. сөйл. к.* **һайтлау**. *Безнең акырып-бакырып һайдалавыбызга карап, атлар бер генә атлыйлар да таеп тезләнәләр, егылалар.* Г.Ибраһимов

**ҺА́ЙДИ** *ы.* 1) Нинди дә булса гамәлгә өндәп дәртләндерүне, әйдәкләүне, теләкне, үтенечне белдерү өчен әйтелә; әйдә. *Заман – тәрәккый заманы. Һайди, карендәшләр, тырышалым, тәрәккый идәлем.* Г.Тукай. *Йосыф мирза ханәкәгә үтте. – Һайди, атакай, узың! – диде кыз.* Р.Батулла

2) Берәр нәрсә эшләргә чакыруны, кушуны, этүне, әйдәкләүне белдерү өчен әйтелә. *– Һайди, Закир, тагы бер сук! Тагы бер! Тагы! – Һайди, Алмачуар! – Һайди, Күк бия! – Һайди, Алмачуар! – Һайди, Күк бия!.. Ике яклап безне каулыйлар... Кычкыралар, сугалар, шаулашалар.* Г.Ибраһимов

**ҺАЙ-ЛИ** *ы.* Кайбер җырларның кушымтасында музыкаль фраза буларак кулланыла; ай-ли. *Һай-ли, замана, замана узып бара.* Җыр. *Һай-ли, Гөлҗамал, Көтүләре бик яман. Бичәлеккә алам диеп, Көтәм дә көтәм һаман.* Җыр

**ҺАЙТ** *ы.* 1) Терлекне куганда яки җәнлекләрне куркытканда кычкыру өчен кулланыла. *Әти билендәге капчыгын ипли, өч сажиннан ала торган, үзе белән яшьтәш чыбыркысын бөтен авыл буен яңгыратып бер шартлата да, малларга якын килеп, куе калын тавышы белән: – Һайт, малкайлар! – дип, көтүгә кузгалырга әмер бирә.* Г.Ибраһимов. *Очына, ярсына, арт аякларына басып кешни, җаным. «Һайт, Кашка!» – дип кычкырып җибәрүем булды, таныды, бахыр, минем якка борылды...* И.Юзеев

2) Кемгә дә булса мөрәҗәгать итеп, куркытып һ.б.ш. очракларда әйтелә. *Бу хатынның сиңа һайт дип өсләп, әмер биреп торуы да артык: сыңар сүзен ишетүгә үк, шәм шикелле катып каласың.* В.Имамов. *Кинәт мине унбиш фриц урап алдылар. – Һайт, русишен, күтәр кулларыңны! – дигән булалар болар, үзләре шырык-шырык көләләр.* Г.Афзал

3) Хуплау, дәртләндерүне белдерү өчен кулланыла. *Кунакларның моңа бик тә кәефләре килә, барысы да шаулап көләргә, ә кайберләре исә әтәч кагынган шикелле терсәкләрен җилпеп: «Һайт сине, әйт шуны!» – дия-дия такмакларга тотыналар.* Ә.Еники

◊ **Һайт дигәнгә тайт дип тору** *к.* **айт дигәнгә тайт дип тору**. *Барысы да, Ихлас Булатов әйткәнчә, һайт дигәнгә тайт дип кенә торырга тиешләр, дип уйлыйсың син.* Р.Батулла. *Кай-*

*да әле безнең һайт дигәнгә тайт дигән Интернет?* Р.Вәлитова

**ҺАЙТЛА́У** *ф.* Һайт дип кычкырып, кемне яки нәрсәне дә булса куу, куркыту яки чакыру. *Кыз исә һаман тибенде, һаман кычкырды. Зәбир тагын бер тапкыр һайтлагач кына борылып карады ул, аннары бу якка чабып килә башлады.* Г.Гыйльманов. *Балалары, Рәйсәсе белән ат ярышын карап утырган Рәшитнең куанычы эченә сыймады, үз колхозларының чаптарлары, аннан юртаклары өчен җан атты, малай-шалай сымак һайтлап-сызгырып, хатынын ачуландырып бетерде.* Д.Булатова

**ҺА́ЙТТИ** *ы. к.* **һайди**. *Ул чыбыркысын шартлатып куйды. – Һайтти! Әйдә, алдырыгыз, арысланнарым!* Х.Кәрим. *Үзе [Ирек] шундый шат, үзе елмая, җитмәсә, һайтти! дигән булып, сине котыртып маташкан була...* Н.Фәттах

**ҺА́ЙТ-ҺАЙТ** *ы. кбт. форм. к.* **һайт**. *Шулай йокысыз гына ял итеп алгач, Сафа, торып, чыбыркысының очын көтү ягына таба аттырып бер шартлатты да: – Һайт-һайт! Кузгалыгыз! – дип сөрән салды. Көтү кыймылдашып куйды.* М.Галәү. *Атларны төнгелеккә көтәргә алып барыр булса, ул һайт-һайт дип сөрән салмый, бер көй сызгырып җибәрә.* Ф.Вахитов

**ҺАЙТҺАЙТЛА́У** *ф. к.* **һайтлау**. *Каршы килеп, үзеңне һайтһайтласа нишләрсең?* Ә.Әминев. *Ә алар... кеше арасында бик үк артта сөйрәлмәсәләр дә, һайтһайтлап алдан да чапмыйлар.* Д.Булатова

**ҺАЙ-ҺАЙ** *ы.* 1) Үкенеч, күңелсезлек хисләрен белдерү өчен кулланыла. *Пәйгамбәрдән калган дин урнына килгән чегәннәрдән Үзенә башка бер дин, кайдадыр исламымыз, һай-һай!* Г.Тукай. *Бүгенгә ярты авыл тол хатын, ә сугыш беткәнчек, анаем, һай-һай, күпме вакыт үтәр – кем калыр, кем юк.* В.Ильясов

2) Гаҗәпләнү, соклану хисләрен белдерү өчен кулланыла. *– Һай-һай, су сөлеге бу Газинур! – диде бераз уйланып торгач, бөтенләй икенче тавыш белән.* Г.Әпсәләмов. *Һай-һай, кызу кеше икәнсең...* Г.Әпсәләмов

**ҺАЙҺАЙЛАП** *рәв.* 1) Шатланып, сокланып яки куркудан шау-гөр килеп, кычкырып. *Тиле кебек әле кычкырып һайһайлап көлде, әле җыр башлады.* Г.Әпсәләмов. *Халык, кул чабып, сызгырып, һайһайлап, теге малай биегәнне карап, гайрәт биреп тора.* З.Зәйнуллин

2) Кемне яки нәрсәне дә булса куалау, әйдәү яки куркыту максаты белән кычкыра-кычкыра. *Һай, урап та күрсәткән иде төймәләрен, тормыш йөген һайһайлап әйдәләп бара торган дилбегәсен иң ышанычлы урынга бәйләгәнмени!* Л.Ибраһим. *Хәлим белән Майя ятып торган сыерны һайһайлап торгыздылар да кайтыр сукмакка төштеләр.* Г.Гыйльманов. *Төлкене куркытырга теләп, һайһайлап кычкырдылар.* Н.Хәсәнов

**ҺАЙҺАЙЛАШЫП** *рәв. к.* **һайһайлап**. *– Безне коммуннарга – жуликларга бай дип күрсәткән иде, – дип шатланып, һайһайлашып тордылар.* Г.Толымбай

**ҺАЙҺАЙТЛАП** *рәв. к.* **һайһайлап**. *Һайһайтлап һаман атлар куылды, киртә арасында алар торган саен кимеде.* Д.Бүләков

**ҺАЙҺАУЛАП** *рәв. к.* **һайһайлап**. *Аучының зиһенен Акбүре чуалттымы, егетләр, һайһаулап, ташларны кулдан кулга күчерә башладылар.* Р.Батулла. *Ил өчен кем кадерлерәк: чатырда бызлап утырган тол хатынмы, әллә киң күкрәкле айгырын һайһаулап, хәләл җиргә басып кергән дошманнарның башын кыйган батыр ир – йөзбашы Яхъя бәкме?* З.Мурсиев

**ҺАЙ-Һ́У** *ы. фар.* **1.** Берәр нәрсәгә әйдәп, дәртләндереп яки малларны кычкырып куу өчен кулланыла. *Ул бaрактан чыккач, --- неводчыларның һай-һу тавышлары ишетелеп, --- кешеләр ду килеп акыра-бакыра вал әйләнәсендә йөгергәндә, ул ялгыз гына, хаста кеше кебек, пальтога төренеп йөрсен, имеш...* Ш.Камал. *Алар баштарак, һай-һу килеп, камчыларын айкыйайкый, урамның бер башыннан икенче башына чабып йөрделәр.* Г.Бәширов

**2.** *и. мәгъ.* 1) Бер урындагы күп кеше авызыннан чыккан төрле тавышлар гөрелтесе, шау-шу. *Хан урдасы корылып, Кылдай мәйдан тартылып, Ун мең казан аш салып, Ун мең төтен ут ягып, Һай-һу тагын башланды.* Дастан. *Нурлы битләр дә балкыган нур иде, бу кайгулар Кай тарафтан чорнаган битләрне? Кайда һай-һулар?* Ф.Ибраһимов

2) Берәр нәрсәгә әйдәп, дәртләндереп кычкыру тавышлары. *Аның дәртле һай-һулары, шаян җырлары бер генә минутка да тынмый.* Г.Әпсәләмов

**ҺАЙ-ҺУЙ** *ы. к.* **һай-һу**. *Алып килгән баллар эчелә, пешерелгән ашлар ашала башлады, һай-һуй кирәкме, җыр кирәкме, бию кирәкме – берсе дә калмады.* М.Әмир. *Ераклашкан ат тоягы, һай-һуй тавышлары [ишетелә].* Н.Исәнбәт

**ҺАЙҺУЛА́У** *ф.* Һай-һу тавышлары чыгарып шаулашу, кычкыру, шау-гөр килү. *Алып Бәргән бер өер атлыларның һайһулап арттан чапканын ишетте.* Р.Батулла. *Юкка гынамы шигырьләребезгә дала исе бәреп керә, кылганнар йөгерә, һайһулап җайдак чабып уза, меңләгән атлар, өер булып, хәтфә үлән утлап йөри ...* Р.Зәйдулла

**ҺАЛӘ** *и. гар.* 1) Нинди дә булса бик якты әйбер тирәсендәге балкышка охшаш нур, яктылык каймасы; ореол. *Ай һаләсе*

2) Икона, миниатюра һ.б.ш.да сурәтләнгән әүлия затларның баш тирәсен уратып алган нур, яктылык боҗрасы; нимб

**ҺАМ** *иярт.* 1) Нәрсәне дә булса кинәт капканда, тешләгәндә барлыкка килгән тавышны белдерә (ешрак эт тур.). *Килгәч керә алмый аптырадым: ат белән керергә – зур капка бикле, кечкенәсеннән керсәм, бер көтү эт бар, һам! дип өзеп алырга торалар.* Г.Ибраһимов. *Иремә дә кирәгем юк икән. Һәм, әйтсәм дә, урталай өзәм: һам!* Р.Рахман

2) *к.* **һау**

**ҺАМАЛА́У** *ф. сир.* Һам-һам дип өрү. *[Этләр] һамалап-һамалап өрделәр.* М.Әмир

**ҺА́МАН** *рәв. фар.* **1.** 1) Хәзергә чаклы, шушы вакытка кадәр, әлегәчә, һәнүз. *Ире, клуб тирәсен урап кайтам әле дип, кичтән чыгып киткән икән дә әле һаман кайтмаган икән.* Ф.Баттал. *Без инде берничә ел дәвамында дәреслекләргә заказ бирәбез, ә алар һаман да юк...* В.Беляева. *А, ул матур төн, ул айлы төн һаман истә.* З.Мәхмүди

2) Һәрвакыт, гел. *Һаман акча сезгә. Ә миңа рәхмәт җитә.* Ә.Баян. *Безгә һаман күбрәк кирәк, тагын да артыграк кирәк!* М.Вәлиев

3) Өзлексез, бертуктаусыз. *Баскынчылар сафында үлем-китем саны һаман арта торды.* В.Имамов. *Нигә алар Һаман ераклаша бара бездән, Ераклаша бара гамәлләре?* Г.Морат

**2.** *терк. функ.* Барыбер, шуңа карамастан. *Бүрене күпме генә ашатма, һаман урманга таба карый.* Мәкаль

◊ **һаман саен** 1) Гел, һәрвакыт. *Чакырма син мине һаман саен, Өметеңне*

*юкка багълама.* Р.Мортазин; 2) Торган саен, ара, вакыт һ.б.ш. үтү белән. *Исмәгыйль боларның барысын да ишетте, әмма тора-бара, тавышлар һаман саен ерагая барып, тәмам ишетелмәс булды.* З.Мәхмүди. *Сүз белән мавыгып, канатларын һаман саен әкренрәк җилпи икән кошлар.* Р.Вәлиев

**ҺА́МАН-ҺАМАН** *рәв.* 1) *к.* **һаман** (*2 мәгъ.*). *Әмма һаман-һаман аларга табынып кына яшәп тә булмый.* А.Әхмәдуллин. *Нигә без һаман-һаман үшән ат сыман тәртә арасында йөрергә тиеш?* А.Гыйләҗев

2) Әледән-әле, эзлекле рәвештә. *Соңыннан, һаман-һаман теорияне тирәнәйтә барган саен, ул мәсьәләдә ачыклык күрә бардым...* А.Алиш

**ҺАМАЮН** *и. фар. миф. к.* **һомай**. *Сәерсенмә, зинһар, соравыма, Җанга тынгы гына эзлимен: Ханбикәсе, биреп һамаюнын, Саклап калган, димәк, үз илен.* З.Мансуров

**ҺАМ-ҺАМ** *иярт. к.* **һау-һау**. *Бәхеткә каршы, ул ераграк булды, күреп, һам-һам дип безгә сикергәнче, ишектән кереп өлгердек.* Г.Ибраһимов. *Мансур абый Акбайга азык бирде булса кирәк, эт һам-һам килде дә, аның да тавышы тынды.* Р.Сабирҗанова

**ҺАҢ** *иярт.* Аккош кычкырган тавышны белдерә. *Аккош китә һаң итеп, Исәнләшеп моңлы итеп.* М.Укмасый

**ҺАП** I *ы.* Сикергәндә, биегәндә һәм башка төрле киеренке эш-хәрәкәтләр башкарганда хуплау, дәртләндерү өчен әйтелә. *Саескан ара-тирә: – Әйдә, һап! – дип көч бирә.* Ф.Кәрим. *Гаепләштән булмасын, тәкъсир, бу таяк белән мин сиңа орсам, син ике генә түгел, дүрт аяклы булырсың! Һап!* Н.Исәнбәт. *Һап, һап, һап кына, Очар коштай талпына. – Үчти-үчти итәм, – ди, – Тәпи атлап китәм, – ди.* Р.Зәлиева

**ҺАП** II *иярт.* 1) Нәрсәнедер кискен хәрәкәт белән авызга кабып җибәрү, тешләп алу, йотып җибәрү рәвешен белдерә. *Кабартманың тырт итеп Дуңгызның танавы өстенә сикереп менүе булган, тегесе – һап, кабып та йоткан.* Р.Вәлиев

2) Кемне яки нәрсәне дә булса кисәк эләктереп алу, тоту рәвешен белдерә. *Үз юлына таба кинәт борылып киткән иде, ди, һап! Эләктереп алдылар, ди, аны министрның солдатлары...* А.Алиш. *Әгәр дә мәгәр, берәрсе киреләнеп йөрсә, аны шунда ук һап итеп эләктереп алалар да милициягә озаталар икән.* И.Диндаров

◊ **һап та һоп** *к.* **һап-һоп**. *Силби чиләк өстендә Киерелеп утыра. Шоколадны һап та һоп Авызына тутыра.* Х.Халиков

**ҺАПТЕЧҮ** *иярт. к.* **әптчхи**. *Кочакла да кызны, син әйт, имеш: «Мин... һаптечү, сине... һаптечү».* М.Җәлил

**ҺА́П-ҺОП** *иярт.* 1) Сугу-кагудан чыккан тавышны һәм кагу-сугу рәвешен белдерә. *(Бал белән массаж ясаганда) тора-бара һап-һоп сугулар кискен һәм көчле булырга тиеш.* Хезмәт даны

2) *к.* **һап** II (*1 мәгъ.*). *Комбайн, ач тамак, һап-һоп бодай ашый-ашый, көнбагарга якынлаша!* Н.Гыйматдинова

**ҺАПЫЛДАТУ** *ф.* 1) Нәрсә белән булса да һап иткән тавыш чыгару. *Актырнак, тиз генә икмәккә сикереп, үзенең зур авызын һапылдатып, аны шундук йотып җибәрде.* Ак юл

2) Аяк киеме белән идәнгә нык басып, характерлы тавыш чыгару

3) Тиз генә кабып йоту

4) *күч.* Көчләп тартып алу, үзләштерү. *Тауны, Шакир һапылдатмаса, бүтән һапылдатыр иде.* Н.Гыйматдинова

**ҺАПЫЛДА́У** *ф.* Нәрсәдер һап иткән тавыш чыгару. *Һапылдаган тавышлар ишетелде*

**ҺАТИФ** *и. гар. иск.* 1) Гаиптән аваз салган кебек хәбәр бирүче фәрештә

2) *күч.* Күз белән күреп булмаган рухи дөнья, гаип. *Безгә күктән, һатифтән тавыш килә.* Г.Камал. *Һатифтән: «Ишеттек, ишеттек, үткәнне сөйләмә, киләчәкне сөйлә», – дигән тавыш ишетелде.* Г.Исхакый

**ҺА́У** *иярт.* Эт өргән тавышны белдерә. *Урман юлында юлыккан кешеләргә, аеруча балаларга, һау дип тә әйтәсе булмагыз!* А.Хәсәнов

**ҺАУЛАТУ** *ф. йөкл. юн. к.* **һаулау**. *Әсләм абыйлары авылны читләтеп үтеп баруын чамалап, алар [балалар], чаңгыга баскан көе, этләр һаулатып, Әсләмне каршы алырга чыктылар.* Ә.Гали

**ҺАУЛА́У** *ф.* 1) Өрү; һау-һау иткән тавышлар чыгару. *Зур, усал эт аны һаулап каршы алды.* Г.Ибраһимов. *Әнчек этләр йөрер һаулап.* Г.Морат. *Маңкортлардан зомби туачак. Ул чагында зомбизобанилар, Кызганмыйча хәтта үз милләтен, Һаулап өрә-өрә, чыбыркылап, Һәлакәткә таба куачак.* Ф.Тарханова

2) Һай-һу куптару, хуплап, дәртләндереп гү килү. *Ни гаҗәп: иң куәтле бәкләр дә бу фикерне һаулап күтәреп алмады. Мәйдан «Явыз», «Рәхимсез», «Дәһшәтле» Иванның бу миһербанлылыгын, бала җанлылыгын һаулап хупләды.* Р.Батулла

3) Ризасызлык белдереп, гаепләп һ.б.ш. очракта тавыш күтәрү, талаша башлау

**һаулый башлау** Һауларга тотыну. *Үзең беләсең: обкомның бер ишарәсе булуга һаулый башларга әзер торучы кутыр кәнтәйләр җитәрлек бездә! Ә болай бер мин генә – бары бер кеше генә гаепле булып калды.* М.Госманов

**ҺАУЛАШУ** *ф. урт. юн. к.* **һаулау**. *Этләр, һаулашып, шуңа ябырылдылар, аларга инде качаклар да, сакчылар да кирәкми иде.* Ф.Бәйрәмова. *Безнекеләрнең тел белмәүләреннән файдаланып, тегеңә килеп сүзката, теге саткан аяк киемнәрен караган була, үзләренчә һаулашып сөйләшә.* Р.Латыйпов. *Башка һаулашып тормадым. Шулай итеп, көтмәгәндә, һич юкка уеннан уймак чыкты да куйды, җәмәгать.* В.Садыйков

**һаулаша башлау** Һаулашырга тотыну

**ҺАУҺАЙЛА́У** *ф. к.* **һаулау**. *Өч урам килеп чапырышкан урында үсүче каеннар әлеге ташкын эченә һауһайлап куалап кысрыкланган тере җаннарны хәтерләтәләр.* Ф.Садриев

**ҺА́У-ҺАУ** *иярт.* **1.** *кбт. форм. к.* **һау**. *Викторның палатка янында әйләнгәләп өреп йөргән аю аулаучы эте Пират янына кунаклар ягыннан Фёдор Чусовитинның Найдасы чабып килеп җитте, һәм ике таныш эт, күрешү сөенеченнән һау-һау өргәләп, бербереен сәламләргә, үзара иснәшергә тотындылар.* И.Хуҗин

**2.** *и. мәгъ.* Өрү, өрү тавышы. *Аларны җиңү өчен, Дүрткүзнең һау-һавы гына ярдәм итә алмас шул.* К.Җәмит. *Колакларда – исерекләр сүгенүе, бульдог, овчаркалар һау-һавы...* Р.Фәйзуллин

**ҺАУҺАУЛА́У** *ф. к.* **һаулау**. *Кешефәлән юк, хәтта этләр дә гадәтенчә һауһаулап чыкмыйлар.* И.Хуҗин. *Чытырманлыкны актарып бетереп килгәндә, Бояр бакчасы ягыннан һауһаулап эт өргәне ишетелде.* А.Тимергалин. *Егетләр дигәннәре һауһаулап җавап бирделәр...* Ф.Бәйрәмова

**ҺАУ-ҺУ** *ы. фар. к.* **һай-һу**. *Һауһу итеп, бер тарафтан килеп тә җиттеләр.* К.Насыйри. *Әле генә, куштанланып, кунакларга булышып йөргән шкипер, кинәт ут чыккандай: – Тукта-*

*гыз, шайтаннар! Күзегез чыккырлары, бөтен ныгытмаларны җимерәсез ич! – дип, яман сүзләр белән сүгенә башлады, аннан катырак ярсып, бурзай һау-һу куптарды.* С.Сабиров

**ҺАУҺУЛА́У** *ф. к.* **һаулау**. *Бернича эт утыра. Чит кешеләрне күргәч, алар тынычсызлана, һауһулап өрә башлады.* Р.Кәрами. *Уятып авылым этләрен, Капкалар шыгырдап ачыла. Әнә бит һауһулап Актүш тә, Чит кеше кергә, дип ашыга.* Г.Гаффарова

**ҺА́-ҺА** *иярт.* Кычкырып, шаркылдап көлү тавышын белдерә. – *Һа-һа, син әллә ниләр беләсең, Приск, – диде префект Ромул һәм, атын куалап, үз илчеләре янына чапты.* М.Хәбибуллин. *Рухия уйлап куйды: рухлар да көлә икән… Рух микән соң ул?.. – Һа-һа-һа!.. Мин бит Май – Дөнья Иясе… Ничек сөт-каймак булыйм ди? Һа-һа-һа!..* Г.Гыйльманов

**ҺА́-ҺА-ҺАЙ** *иярт. к.* **һа-һа**. – *Һа-һа-һай! – дип шатланган Баһбай.* Ә.Гаффар. *«Һа-һа-һай!» – дип бераз калынрак Дәшкән иде – дәште урамнар.* Ф.Яхин

**ҺАЧ** *иярт. к.* **эптчхи**. *«Җаным» дим дә «һач» дип бер төчкерәм.* М.Җәлил

**ҺАЧТ** *ы.* Терлекне кычкырып куу өчен кулланыла. *Карт: – Һачт! Һачт! – диюгә, акрын, уңай күтәрелеп, сахра корабы аякка басты.* Г.Ибраһимов

**ҺӘ** *ы. к.* **һа**. *Һә, җиде йөз тәңкә файда иттеләр, диген, ә? Бер көндә җиде йөз тәңкә!* Г.Камал. *Һә, таптың сүз!* Г.Бәширов. *Кайберәүләр, юлларын мәче киссә, туктап, берәрсе үткәнен көтәләр. Янәсе, аныкын түгел, башка берәүнең юлын кисә. Һә! Алдарсың алай гына язмышны!* Ә.Дусайлы

◊ **һә дигәнче** *к.* **ә дигәнче**. *Һә дигәнче үсеп җитәр – Тиз оча ул гомерләр.* Ф.Галиева. *Балалар бакчасына яшь кыз эшкә килү хәбәре Тозлыкушины һә дигәнче урап чыга.* В.Мәҗитова

**ҺӘВӘС** *и. гар.* **1.** Теләк, арзу; дәрт, омтылыш; тартылу. *Үзе бәгъзан яна, көя, өмитсезлеккә төшә, кайбер чакта бик зур дәрт вә һәвәс илә дә керешеп, өмитенең якынаюын да хис итә башлый иде.* Г.Ибраһимов. *Белемгә һәвәсе күренеп торган сәләтле улын Габделмәҗит хәзрәт тагын да ышанычлы кулга тапшырырга уйлаган булса кирәк, шуңа күрә Габделҗәббар мәдрәсәдән мәдрәсәгә күчеп йөргән.* М.Госманов

**2.** *с. мәгъ. к.* **һәвәсле**. *Безнең яшьләр яңага бигрәк һәвәс шул.* Г.Әпсәләмов. *Авылдашының табын алып барырга һәвәс икәнлеген Рәнис моңарчы белми иде әле.* Ж.Дәрзаман

**ҺӘВӘ́С ИТҮ** *ф.* Нәрсәнедер теләү, арзу итү. *Вә дәхи, әй угыл, бурыч итәргә һәвәс итмә.* К.Насыйри

**ҺӘВӘСКӘР** *и. фар.* **1.** 1) Нәрсә белән дә булса кызыксынучы, мавыгучы кеше. *Хәтерләре шигырьләр белән тулы һәвәскәрләр күп.* Г.Хөсәенов

2) Махсус белем һәм квалификация алмыйча, берәр эшкә үзлегеннән өйрәнеп, шуның белән кызыксынып, мавыгып шөгыльләнүче кеше; үзешчән. *Соңгы елларда узган тарихыбыз белән кызыксыну махсус белемле тарихчылар арасында гына түгел, ә туган якны өйрәнүче һәвәскәрләр арасында да бермә-бер артты.* Ф.Фәтхи. *Тавышлары бик матур, моңлы булган бу һәвәскәрләр тамашачыны таң калдырды.* Х.Хаҗимов

3) *күч.* Эш рәтен белмичә эшкә керешүче, эш бозучы кеше

**2.** *с. мәгъ.* 1) Махсус белем һәм квалификация алмыйча үзлегеннән өйрәнгән. *Һәвәскәр артистларның чыгышын милләттәшләребез һәрчак көтеп алалар.* Я.Шәфыйков. *Кызганыч, бөтен «Тулпар»ны иңгә-буйга айкап чыксам да, һәвәскәр итек басучыны очрату насыйп булмады.* Л.Закиров

2) Профессионал булмаучылар тарафыннан эшләнгән, башкарылган, ясалган. *Кыз бала сурәтен ул Таңсылу ханымның сабый чактагы һәвәскәр фотосыннан күчергән.* А.Тимергалин. *Үзешчән сәнгать коллективында һәвәскәр спектакльләрдә һәм концертларда мин башлап йөрүчеләрнең иң активы булып киттем.* Ә.Рәшит. *Язучы Рабит Батулла төшергән һәвәскәр видеоязмалар кулланылган.* Н.Алан

**ҺӘВӘСКӘРЛӘ́РЧӘ** *рәв.* 1) Һәвәскәрләр кебек, шулар шикелле. *Шулкадәр комплексны тик тотып булмый бит инде – башта эшне һәвәскәрләрчә башлыйлар.* Ә.Рәшит

2) Эшнең рәтен белеп бетермичә; җиренә җиткермичә, аннан-моннан

**ҺӘВӘСКӘРЛЕК** *и.* 1) Һәвәскәр булу хәле. *Ул заманда ярым кустарьчылык, ярым һәвәскәрлек белән эшен алып барган труппада, әлбәттә, хәзерге без белгән тәртиптәге хәзерләнү булмаган.* Ә.Еники. *Шул ук вакытта Гыйффәт туташ – «һәвәскәрлек» белән «үзешчәнлек» чикләрен узган шагыйрә.* Т.Галиуллин

2) Булдыксызлык

**ҺӘВӘ́С КЫЛУ** *ф. к.* **һәвәс итү**. *Малик таҗир сараена хазир килең, Ул угланны күрмәккә һәвәс кылың.* Кол Гали

**ҺӘВӘСЛӘНДЕРҮ** *ф. йөкл. юн. к.* **һәвәсләнү**. *Яшерен-батырын түгел, бу хыял Маратның үзен дә бик җылыта, һәвәсләндерә иде.* Д.Гыйсметдин. *Балаларны уңай якка көчләп түгел, ә һәвәсләндереп тартырга кирәк.* Ә.Хуҗиәхмәтов. *Ибраһим студентларны язучының иҗатын беренче чыганаклардан өйрәнергә һәвәсләндерде.* Р.Нуруллина

**ҺӘВӘСЛӘНЕП** *рәв.* Дәрт белән, теләп һәм бирелеп. *Картлар һәвәсләнеп, бар дөньяларын онытып җырлыйлар.* И.Диндаров. *Көн дә күрә торган этләр, песиләр турында шулкадәр һәвәсләнеп сөйли, укучылар, кайдалыкларын онытып, авыз ачып тыңлап утыралар.* Ә.Моталлапов

**ҺӘВӘСЛӘНҮ** *ф.* Нәрсә белән дә булса мавыгу, кызыксыну; нәрсәгә дә булса бирелү, шуңа тартылу. *Шаһикамал җаныем, мин соңгы вакытта үзбәк дусларымның җырларына колак салырга һәвәсләндем бит әле.* Т.Әйди. *Аучы да, балыкчы кебек, бер һәвәсләнсә, бу шөгыленнән туктый алмый.* Шәһри Казан

**һәвәсләнә башлау** Һәвәсләнү билгеләре сизелү. *Бу кыш мин мөхәррир булырга һәвәсләнә башладым.* М.Фәйзи

**һәвәсләнеп йөрү** Күпмедер вакыт һәвәсләнү. *Ул чакларда мин дә шулай һәвәсләнеп йөрдем.* Д.Гыйсметдин

**һәвәсләнеп китү** Соңгы вакытта һәвәсләнү. *Атасына охшап, ул бик яшьли балык тотарга, җәнлек эзәрлекләргә һәвәсләнеп киткән иде бугай…* Ә.Еники. *Шиһап карт, пенсиягә чыккач, радио тыңларга бик һәвәсләнеп китте.* Ф.Яруллин

**ҺӘВӘСЛЕ** *с.* Нәрсәне дә булса кулга төшерергә, өйрәнергә яки шуның белән шөгыльләнергә зур теләге булган, шуңа бик теләп кереп китүчән, бирелүчән, шуның белән нык мавыгучан; әвәс. *Безнеке музыкага алай һәвәсле түгел, башка уеннарны бик ярата.* К.Тинчурин

**ҺӘВӘСЛЕК** *и.* Һәвәс булу сыйфаты. *Мәктәптә укыганда ук, рифмалап такмаклар чыгарырга һәвәслеге бар иде.* Марс Шабаев. *Мәктәпкә кабул итү өчен тагын бер шарты бар: ул да булса – математикага һәвәслек.* Ш.Җиһангирова

**ҺӘВӘССЕЗ** *с.* Ваемсыз, битараф; кызыксынуы булмаган. *Дәвасыз дәрт*

*булмас, һәвәссез карт булмас.* Мәкаль. *Әгәр дә сез бик һәвәссез, зур тизлекләргә битараф түгелсез икән, машинада җилдереп, адреналиныгызны арттыра аласыз.* Кама таңнары

**ҺӘВӘССЕЗЛЕК** *и.* Ваемсызлык, гамьсезлек; кызыксыну булмау

**ҺӘВӘССЕНҮ** *ф. сир. к.* **һәвәсләнү**. *Надяның бу һәвәссенүе куәтлерәк булып чыкты: аңа чебешләр тәрбияләүне тапшырдылар.* М.Шабай

**ҺӘДӘФ** *и. гар. иск.* 1) Мишень, нишан, мәрә. *Һилалдик кашларың – җәя ирер, керфекләрең – уклар, һәдәф аңа минем мәҗрух күңлем.* М.Иманколый. *Аткан ук һәдәфкә тиде*

2) *күч.* Максат, гая, ирешү теләге булган нәрсә. *Безнең голәма вә ахуннарымыз, ниһаять ялкау вә гыйлем куәтеннән бөтенләй мәхрүм булдыкларыннан, --- аңлау вә тикшерү бәласеннән котылуны һәдәф итеп тоталар, бәс, авыз тутырып, алар, бу – исламда бидгать, диләр, харам, диләр.* Г.Буби

**ҺӘДИЯ** *и. гар. иск.* Сөю яки хөрмәт билгесе буларак бирелгән әйбер; бүләк. *Кичәләрнең берсендә: «...Клуб идарәсенең үзе тарафыннан бирелгән һәдия илә бәрабәр мәҗлескә хазир булган бәгъзе бер кешеләр тарафыннан да мәзкүр балага һәдияләр бирелде», – дип яза газета.* М.Мәһдиев. *Ул һәдия дә – син һәм синә булган мәхәббәтем.* Г.Ибраһимов

**ҺӘДИЯ́ ИТҮ** *ф.* Бүләк итеп бирү. *Дөрес юраган адәмгә үз кулым белән үз атымны һәдия итәмен.* Р.Батулла

**ҺӘДИЯ́ КЫЛУ** *ф. к.* **һәдия итү**. *Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында (элеккеге бинасында) концерт тәмамлангач, Фәридә Кудашевага үземнең юка гына китабымны һәдия кылдым.* Г.Гомәр

**ҺӘЙ** *ы. к.* **һай**. *Һәй, бу җил миңа таныш ич!* В.Хәйруллина. *Һәй, җаным, ир-атны хатын тотып торырга калгач – булмый инде ул!* В.Нуруллин. *Һәй, саран кортка!..* Н.Гыйматдинова

**ҺӘЙӘТ** *и. гар.* 1) Делегатлар төркеме, делегация. *Шундагы ихтыяҗны белер өчен, Петроград комитеты, беренче уларак, акчалар, әйберләр берлән бер һәйәт күндерергә вә шул һәйәт арасына мөселман депутатларымыздан берничә кешенең керүе мотлакан лаземдер, тиештер.* Г.Исхакый. *Фаҗиганы тикшерү өчен, абруйлы журналистлардан торган һәйәт төзелде.* А.Тимергалин

2) *иск.* Астрономия. *Идел буе Болгар йортында 922 елда ислам дине тәмам рәсмиләштерелгәннән соң, төгәл фәннәргә, шул исәптән һәйәт гыйльменә яки голүме нөҗүмгә – астрономиягә ихтыяҗ арткан.* А.Тимергалин

**ҺӘЙБӘТ** *с. гар. иск., диал. к.* **әйбәт**. *Менә, Аллаһы теләсә, Габдулла кайтыр да бик һәйбәт мулла булыр.* Г.Исхакый. *Һәйбәт мунчадан баш тарта аламмы инде мин?* К.Тимбикова

**ҺӘЙБӘТЛӘНҮ** *ф. к.* **әйбәтләнү**. *Хәзрәтнең тормышы да һаман һәйбәтләнүгә табан барды.* Һ.Такташ. *Кеше җаным, һәйбәтлән син, хушбуй сөртен: Хыялланып үтеп китте тагын бер көн* Р.Бәшәр

**Һәйбәтләнеп китү** *к.* **әйбәтләнеп китү**. *– Кояш аязга баеды, иншалла, көннәр һәйбәтләнеп китәр, боерган булса, – дип куйды ул.* М.Хәсәнов. *Кызлар халкы шундый һәйбәтләнгән.* К.Сибгатуллин

**ҺӘЙБӘТЛӘП** *рәв. кит. к.* **әйбәтләп**. *Министр килә, дигәч, мәктәп мичләренә дә бик һәйбәтләп яга башладылар.* В.Нуруллин. *Терелеп, аякка гына бассын, әйтәчәк аңа үз сүзен Бикташев, бик һәйбәтләп әйтәчәк!* Н.Акмал

**ҺӘЙБӘТЛӘ́Ү** *ф. к.* **әйбәтләү**. *Ул көнгә дугаларны, тарантас-тәртәләрне һәйбәтләп, ялт иттереп кап-кара лакка буяп куябыз.* А.Хәсәнов

**ҺӘЙБӘТЛЕ** *с. иск.* Күренеше курку белән берьюлы хөрмәт уята торган. *Миңа ул бер вә бар, көчле вә һәйбәтле санәм булды.* Г.Тукай. *Киресенчә, фикернең куәтле сарае кебек күзгә беренче бәрелгән бөек һәйбәтле маңгаен, карамый күрә торган зәкя тулы күзләрен, тәкәллефсез, ләкин олуглык күрсәткән тормышын күрәбез.* М.Салиәхмәт

**ҺӘЙБӘТЛЕК** *и. к.* **әйбәтлек**

**ҺӘ́ЙДӘ** *ы. к.* **һайди**. *Опричниклар: «Һәйдә! Һәйдә!» – дип кычкыра-кычкыра, төрле якка ташландылар.* С.Горский. *– Һәйдә-ә! – дип кычкырды тутай кызларга.* Р.Батулла. *Ара-тирә, ишеген ачкалап: «Һәйдә, һәйдә!» – дип көч бирә.* А.Тимергалин

**ҺӘЙКӘЛ** *и. гар.* 1) Берәр вакыйгага, тарихи шәхескә багышлап салынган архитектур яки скульптур корылма. *Әгерҗедә Таҗи Гыйззәткә һәйкәл ачу тантанасына да бергә бардык.* Г.Гомәр. *Һәйкәлеңне алып атмакчылар Ераккарак халык күзеннән.* Р.Миңнуллин. *Мемориаль һәйкәл*

2) Сакланып калган борынгы мәдәният объекты. *Төркиянең Анкара, Истанбул, Измир, Бурса, Конья, Кайсәри һ.б. шәһәрләрендә урнашкан бай тарихи музейлары, урта һәм борынгы заман археологик һәйкәлләре күп кенә чит мәмләкәт илгизәрләрен бүген дә үзләренә җәлеп итеп тора.* Т.Әйди. *Архитектура һәйкәле буларак мәчет хөкүмәт карамагына алынды.* Р.Батулла // Борынгы язма әсәр. *Әлбәттә, Көнчыгыш Европада Күлтәгин, Тоньюкукка багышланган ташъязмалар кебек мәһабәт язма һәйкәлләр юк.* Татар әдәби теле тарихы

3) *күч.* Кемнең дә булса хезмәтләре һ.б. турында һәрвакыт искә төшереп торган, берәр эш-хәлнең җанлы чагылышы булган нәрсә. *«Колыма хикәяләре» басылып чыкканнан соң, --- тәнкыйть әсәрне «шәхес культы корбаннарына куелган һәйкәл» дип бәяләде.* Л.Минһаҗева. *Атау түрендә авылга ямь биреп, үткәннәргә һәйкәл булып торсын...* Р.Вәлиев

**ҺӘЙКӘЛТАРАШ** *и. гар.-фар. иск.* Скульптор. *«Һәркайсы рәссам да, һәйкәлтараш та, шагыйрь вә архитектор да» булган бу бөек шәхесләрне автор, өч сәнгать даһие, дип атый, аларның исемнәре хәзерге көндә дә Гомер, Данте, Шекспир һәм Гётелар белән янәшә йөртелүен күрсәтә.* Г.Ибраһимов. *Казанда рәссамчылык, һәйкәлтараш, гыймарәтчелек мастерскойлары бар икән.* Ә.Еники

**ҺӘЙКӘЛЧЕ** *и.* Скульптор. *Һәр скульптор һәйкәлче була алмый.* Р.Харис. *Һәйкәлче Урманчега Кол Гали, Тукай, Дәрдемәнд, Җәлил сыннарын оста башкарырга рәссамнар гына түгел, шул ук шагыйрьләр үзләренең шигырьләре белән ярдәм иткәннәр.* Н.Юзиев

**ҺӘЙТ** *ы. к.* **һайт**. *Көлергә дә, еларга да белмәссең, дигәндәй, малай таныш репертуарны төгәлли язганда гына, Ильяс кычкырып көлеп җибәрде: – Һәйт, менә ичмасам җырчы!* Ә.Баян. *– Һәйт! Таптыйм бит үзеңне! – Рәшит сискәнеп китте. Аңа таба гироскутерда бер кыз очыпмы-оча иде!* А.Гыймадиев

**ҺӘЙҺАТ** *ы. гар.* Кулдан ычкынган, югалткан нәрсәдер өчен үкенү, өзгәләнү, хәсрәтләнүне, кызгануны белдерә; ни кызганыч. *Шул үлүләр, шул авырулар, шул изелүләр бетәрме? Һәйһат! Һәйһат!* Г.Исхакый

**ҺӘ́Й-ҺОЙ** *ы. к.* **һайт-һайт**. – *Һәй-һой! – дип кычкырды уен башлыгы. Шул тавышны ишеткәч, этләр җигелгән чанага утырган бер кыз --- кузгалып китте.* Р.Батулла

**ҺӘЛАК** *и. гар.* Үлем; бетү, юкка чыгу. *Әләк төбе – һәлак.* Мәкаль

**ҺӘЛАКӘТ** *и. гар.* 1) Фаҗигалы үлем. *Ахыр чиктә ана, кызының һәлакәт алдында торуын күңеле сизенгәндәй, иренә радикаль чара да тәкъдим итеп карый.* М.Хәсәнов. *Төн уртасында кергәннәрдән берәү Казан губерна юстиция комиссары – егерме өч яшьлек Мартин Межлаукның һәлакәтен хәбәр ит[те].* Казан утлары

2) Тулы җимерелү, юкка чыгу хәле (кризис, сугыш һ.б.ш. сәбәпләр аркасында). *Кайбер галимнәр күптән кисәтәләр инде: әгәр дә җирдә рухи чәчәк ату, рухи ренессанс башланмаса, табигатьне һәм бер-беребезне яратырга өйрәнмәсәк, дөньяны биләп алган контрольсез җитештерү, техник алгарыш кешелекне һәлакәт чигенә китереп терәячәк.* Н.Шәрифуллин. *Әмма онытма: большевиклар илгә, халкыбызга игелек эшләмәячәк, һәлакәт белән бетәчәк һәммәсе!..* Р.Мөхәммәдиев

3) Зур уңышсызлык, матди югалтулар, корбаннар алып килә торган вакыйга, бәла. *Гади кешеләргә, гади хезмәт халкына иксез-чиксез һәлакәт һәм хәерчелек китерде сугыш.* М.Хәсәнов. *Хакимият белән халык бәрелешсә, һәлакәт туа.* Т.Миңнуллин

4) Афәт, каза; зур фаҗига, фәлакәт; катастрофа, авария. *Экологик һәлакәт чоры бу.* А.Тимергалин. *Машинасы тәмам эштән чыккан бит һәлакәт вакытында...* В.Нуруллин

◊ **Һәлакәткә салу** Ахыры фаҗигалы үлемгә китерә торган хәлдә калдыру. *Бәс, моңар бинаән мин Хакның боерыгын тотмыш булырмын, вә син үзеңне һәлакәткә салганың өчен, боерыгын тотмаганнар җөмләсеннән булырсың.* К.Насыйри. **Һәлакәткә ташлау** *к.* **һәлакәткә салу**. *Сугышны дәвам итү – калган гаскәрне да һәлакәткә ташлау булыр иде.* Р.Батулла. **Һәлакәт күзенә карау** Фаҗигалы үлем куркынычы алдында тору. **Һәлакәт тырнагы** Фаҗигалы үлемгә, юк ителүгә илтә торган һәм котылуы имкянсыз дәрәҗәдә булган зур бәла-каза. *Син шәһәрнең чык икенче ягыннан Юлга, качып һәлакәт тырнагыннан.* Фирдәүси. *Ханбалга Альбина бүләк иткән челтәрпәрдәгә ябышты. Гүяки шушы чүпрәк аны һәлакәт тырнагыннан алып кала төсле иде.* Ф.Яхин. **Һәлакәт упкыны** Нинди дә булса үлемгә китерә торган куркыныч. *Инде бүгенге максатыбызны искә төшерик: бүген матур сүзе шундый һәлакәт упкыны алдында тора.* И.Низамов. *Мондый чакта ир кеше нишли: гадәттә, йөрәк ялкынына хәмер утын бөркеп, һәлакәт упкынын якынайта.* М.Галиев. **Һәлакәт чокыры** *к.* **һәлакәт упкыны**. *Дәүләт һәлакәт чокыры алдына килеп баса.* Ә.Фәйзи

**ҺӘЛАКӘТЛЕ** *с.* Һәлакәт китерә торган, һәлак итә торган. *Минемчә, операция алдыннан кичергән рухи газаплар һәлакәтле роль уйнаган булса кирәк: аның йөрәге чыдамаган...* Г.Әпсәләмов. *Август башында Армавир янындагы Совет ягы өчен һәлакәтле сугышларда корпус алман гаскәрләре тарафыннан тар-мар ителә.* Р.Зарипов

**ҺӘЛА́К БУЛУ** *ф.* 1) Вакытсыз гомер өзелү, фаҗигалы үлү, яшәүдән туктау. *Безнең Әхмәт җизни сугышның беренче елында ук Смоленск янында һәлак булды.* М.Талипов

2) Яраксыз хәлгә килү, җимерелү, бозылу. *Әмма һич тә һәлак булган яисә ташландык кораб түгел ул, аның бар җире төзек, экипажы да исән-сау.* З.Мифтахов. *Дүрт-биш айлык үзизоляция режимыннан соң, кече бизнес һәлак була язды. Көчле давылдан соң игеннәр һәлак булды*

3) Бөтенләй юкка чыгу. *Икенче цивилизацияне кешеләр соңга калып ачтылар – ул һәлак булган иде инде.* З.Мифтахов. *Сәүдәгәрнең маллары боз астына китеп һәлак булды*

4) Зур бәхетсезлеккә, фаҗигалы хәлгә дучар булу; кыен хәлгә калу. *Мода дип, бәндәләр киенә бер төрле – Кырны баскан чүп үләне шикелле. Кайда монда нечкә зәвык, кайда әхлак? Кызганыч: шулай милли рух була һәлак.* Р.Ханнанов. *Шуның аркасында күп кенә талантлы язучылар һәлак булды.* Т.Нәбиуллин

**ҺӘЛА́К ИТҮ** *ф.* 1) Үтерү, җанын алу. *Ул пәри, моңа ялынып: – Әфәндем, әгәр дә мине һәлак итми калдырсаң, мин сиңа лаек һәм дөньяда тиңе булмаган бер гүзәлне табып бирүне өстемә алыр идем, – диде.* К.Насыйри. *Юк исә – я үз-үземне һәлак итәрмен, я башка берәр хәл булыр, икемез дә хур булырмыз.* Г.Камал

2) Җимерү; җимерек хәлгә китерү, хәрабә итү. *Ильич әйткән «кухаркалар»дан ашык-пошык әзерләнгән ачкүзле кадрлар, илнең дилбегәсенә чытырдатып ябышып, кул-аякларыбызга зынҗыр-богау салгач, чыннан да, барын да хәл иттеләр – 70 ел эчендә «барын да һәлак иттеләр» дип әйтсәк дөрес булыр.* А.Тимергалин

3) Яндырып, суга батырып һ.б.ш. юллар белән бөтенләй юкка чыгару. *Алар, шәт, профессорның, әгәр аның фондын гитлерчылар яки немец коммунистлары һәлак итмәгән булса, архивларында сакланадыр.* М.Мәһдиев. *Галәм тарихында үзен үзе аңлы рәвештә һәлак иткән цивилизацияләр дә билгеле.* А.Тимергалин

4) Үсүдән, яшәүдән туктату; кыру (үсемлекләр турында). *Бу төбәкләргә төшкән көл бирелдәге бөтен үсемлек дөньясын һәлак итә.* Татарстан яшьләре

5) Зур бәхетсезлеккә, фаҗигалы хәлгә дучар итү; кыен хәлдә калдыру. *Королёвны да, Гагаринны да гумансыз һәм имансыз система бер-бер артлы һәлак итте.* А.Тимергалин. *Һавариянe комсызлык, үз рәхәте турында гына уйлау һәлак итте.* М.Яһудин. *Ул алдады бичара Зәбирәне, Зариф һәлак итте бахыр кызны.* Х.Мөдәррисова

**ҺӘЛА́К КЫЛУ** *ф. иск. к.* **һәлак итү**. *Ягъкуб әйтте: «Әгәр шулай булган булса, Бүре аны ашап, һәлак кылган булса, Әгъзасыннан берәр нәрсә калган булса, Китерегез табып шуны миңа имди!»* Кол Гали

**ҺӘЛАКЛЕК** *и. иск. к.* **һәлакәт**. *Вай безгә үкенеч вә һәлаклек, чөнки без залимнәр булдык.* Ногмани. *Вә падишаһны күрделәр: һәлаклек чигенә җиткән.* К.Насыйри

**ҺӘЛАКЛЕ́К КЫЛУ** *ф. к.* **һәлак итү**. *Замана хакиме охшар еланга. Яшертен дошманлык саклар уенда. Еландай ялтырый тыштан күргәндә, Һәлаклек кылыр ул, форсат йөргәндә.* Һ.Салихов

**ҺӘМ** *терк. фар.* **1.** 1) Бер үк вакытта, параллель рәвештә булган күренеш, эш-хәлләрне белдерә торган тиңдәш кисәкләрне яки тиңдәш җөмләләрне үзара теркәү өчен кулланыла. *Ир-атлар арасында руслар һәм хохоллар күп ---.* А.Әхмәтгалиева. *Әй лә әфәнделәр, бары тик әфәнделәр һәм ханымнар гына!* Г.Каюмов. *Көч һәм сабырлык, өмет һәм ышаныч өстәгез!* Г.Бәйрәмова

2) Берәр нәрсәне характерлый торган парлы сыйфатлар, рәвешләрне терки

һәм шул нәрсәгә хас үзенчәлекләрнең бер үк вакытта табылуын күрсәтә. *Тик миңа Капустиннарны ярты сүздән танырга өйрәнү --- безнең өчен кирәкле һәм мөмкин эштер...* А.Тимергалин. *Алдый белеп алдый шулай дөнья, Хакыйкатьне бездән эзләтеп. Борынгылар аны читтән тапкан, Дога тотып һәм дә тезләнеп.* Ф.Яхин

3) Бер-берсе белән эзлекле һәм сәбәпшарт бәйләнешендә булган җөмләләрне яки җөмләнең фигыль белән белдерелгән тиңдәш хәбәрләрен терки. *Малай, пуля тизлегендә атылып, ишекне ачты һәм... лапылдап идәнгә утырды.* А.Гыймадиев. *Шул рәвешле Көн белән Төн алышынып чыга башлаганнар, һәм Күк йөзендә безгә таныш Кояш белән Ай барлыкка килгән.* Г.Гыйльманов

4) Фикергә аныклык кертә, экспрессивлык өсти торган «шуңа күрә», «шуның өчен», «ихтимал», «менә», «дә» алмашлык, бәйлек, кисәкчә, кереш сүзләр белән килә. *Иреннәре аның кыймылдыйлар, ул нәрсәдер әйтә шикелле, тик тавышы ишетелми... Һәм менә кулындагы ак конвертны әнисенә суза.* Ә.Еники. *Университетта иң гадел, иң таләпчән һәм шуңа күрә иң авторитетлы укытучы санала ди бит ул Булыгин диганнәре.* В.Нуруллин

5) Саналып кителгән сүзләрнең соңгысы алдыннан гына килеп, тиңдәш кисәкләр рәте тәмамланганлыкны белдерә. *Кояш, Ай һәм планеталар төрле тамгалар кушылмасы белән күрсәтелә.* А.Тимергалин. *Алар бу халәтнең ничек, нәрсә белән һәм кайчан бетәсен белмиләр иде...* Д.Гыйсметдин

6) Саналып кителгән һәр тиндәш сүз алдыннан килеп, аларны берләштерә, мәгънәгә көчәйтү төсмере өсти. *Шуннан соң авыл белән шәһәр арасындагы һәм экономик, һәм культура аермасы бик тиз бетәчәк тә, коммунизмга аяк басачак идек...* В.Нуруллин

7) Әйтелгән фикерне тулыландыра, ачыклый торган җөмләләрне яки җөмлә кисәкләрен (өстәлмә конструкцияләрне) теркәү өчен кулланыла. *Күрәсез, бу – тормыш үзе китереп куйган зур проблема, һәм ул чишелергә тиеш...* Г.Гомәр. *Минем беркемне дә сине яраткан кебек яратканым булмады һәм булмас та инде.* З.Хәким

8) Җөмлә башында килеп, мәгънә ягыннан алдагы хикәяләүгә, алда әйтелгән фикергә бәйләнешле җөмләне терки. *Әйе, сөенәм... Һәм башымда, күк гөмбәзен ертып узган яшен сыман, бер уй сызылып китә: ул минеке генә булачак.* А.Мансуров

**2.** *кис. функ. иск.* Үзе бәйләнгән сүз яки сүз тезмәсенең мәгънәсен көчәйтү, ассызыклап күрсәтү өчен кулланыла; да, та. *Мондагы төслүктер анда һәм казакълар гаскәре; камчылар – шул иске камчы, башкалык – тик фәсләре.* Г.Тукай. *Бухгалтерия тәртибенчә тугры йөртелгән дәфтәрләргә мәхкәмәләр һәм ышанып кабул итәләр.* Ш.Мөхәммәдев

**ҺӘМЗӘ** *и. гар. лингв.* Тавыш ярыларының йомылуы һәм кисәк ачылып китүе нәтиҗәсендә ясала торган йомык шартлаулы саңгырау бугаз тартыгы һәм шул авазны белдергән тамга – [ء] билгесе. *Бу канун гарәп хәрефләренә нигезләнгән татар язуы өчен мәҗбүри саналган, чөнки, татар телендә сүз сузык авыздан башлана алмый, дип өйрәтелгән, шуңа күрә сүз башында килгән сузык аваз алдыннан һәмзә язылган.* Ш.Асылгәрәев. *Мәсәлән, соңгы елларда тәкъвим кебек сүзләрдә ирен-ирен [w] урынына ирен-теш [в] әйтү, мәсьәлә, гаилә, сөаль, Гаишә, Наилә, рәис кебек сүзләрдә һәмзәне әйтеп тормау хаталары еш очрый.* Р.Абдуллина

**ҺӘ́МИШӘ** *рәв. иск. к.* **һаман**. *Бохара мәдрәсәләреннән тормыш өчен муафикъ кеше тәрбияләнеп чыкканы юк әле, безнең муллалар шуны һәмишә аңлый алмыйлар.* М.Галәү. *Дәү абыең язмады шул шәҗәрәне. Ни әйттем, һәмишә сүзды.* Г.Бәширов

**ҺӘ́ММӘ** *а. фар.* **1.** Бөтен, барлык, барча, һәр, һәрбер, җөмлә. *Соңыннан һәммә укытучы: «Бәй, кыңгырау сары төстә буламыни ул!» – дип тел шарт-латты.* А.Гыймадиев. *Габдерәшит бабай күзен йомган да битендәге һәммә җыерчыгы белән елмая...* А.Тимергалин

**2.** *и. мәгъ.* Булган һәр кеше; бөтен нәрсә. *Закир, юри шаяртып, аны (яшь киленне) һәммәгә күренерлек рәвештә табынның уртасына тартты: – Нәрсә син?* Г.Ибраһимов. *Бездән тыш тирә-күрше хуҗалыклар, район үзәге, больница, мәктәпләр, фермалар – һәммәбез бушлай нефть ягабыз.* А.Гыйләҗев. *Бер ай узганнан соң, тиле авызын ачкан һәм һәммәгезгә мәгълүм теге җөмләне әйткән.* И.Юзеев

**ҺӘ́ММӘКИ** *а. фар. к.* **һәммә 1.** *Ярабби, аның һәммәки гөнаһларын ярлыка, үзен мәңге җәннәтле ит.* Г.Бәширов. *Шул рәвешчә, Булочкина бу ашханәдә әзерләнә торган һәммәки ризыкны әзерләргә өйрәнде.* Н.Максимов

**ҺӘНДӘСӘ** *и. фар. иск.* Геометрия. *Бу Җегет һәндәсә гыйлемендә бик маһир булырга кирәк: дәрхаль өйне казып, астына кертеп, теләгән җиренә алып барырга бик зур бер чана ясатты.* Г.Тукай

**ҺӘНҮЗ** *рәв. фар. иск. к.* **һаман 1.** (*1 мәгъ.*). *Шәех һәнүз урынында утырыр.* К.Насыйри

**ҺӘР** *а. фар. к.* **һәрбер 1.** – *Һәр өргән эттән курыккач, син чыннан да язма, – диде Тукай.* Р.Батулла. *Һәр сүзне көлкегә борырга торган юантык Гайнигөлеч рәхәтләнеп бот чапты: – Һай, Фәһимә, кеше көлдермә!* С.Лашманчы

◊ **Һәр бирмеш көн** Көн дә, көн саен. *Ә картлыкка таба барганда ярдәмгә мохтаҗлык Алланың һәр бирмеш көнендә геометрик прогрессия буенча арта бара.* Ә.Мушинский. *Һәр бирмеш көн таң ата.* Р.Маннапов

**ҺӘ́РБЕР** *а.* 1) Бер иш кешеләрнең, әйберләрнең яки күренешләрнең барысы да аерым-аерым; һәркайсы. *Санэпидстанциядәге һәрбер кеше фатирлар буенча әллә ничә тапкыр йөреп чыкты.* В.Имамов. *Күпер-дуга! ...Һәрбер чыңы аның Тойгыларга килеп кагылган.* Зөлфәт

2) Теләсә кайсы, теләсә нинди, очраган бер. *Гел сагаеп яшидер күк, Гел сагынып яшидер. Шуңа һәр кош ахир аңа, һәрбер җәнлек яшьтидер.* Г.Морат. *Җирнең түгәрәк икәнен һәрбер мәктәп баласы да белә бит инде, коллега...* Г.Афзал

**ҺӘ́РВАКЫТ** *рәв.* Теләсә кайчан; өзлексез, даими рәвештә, даимән. *Кечесен-олысын аерып тормый, кешеләр белән һәрвакыт башлап үзе исәнләшә.* В.Нуруллин. *Күз тимәсен өчен, әни һәрвакыт, сөбханалла, дип әйтергә куша.* З.Хәким

**ҺӘ́РВАКЫТТА** *рәв. к.* **һәрвакыт**. *И сабыйлар, эшләгез сез, иң мөкатдәс нәрсә – эш; Эш агачы һәрвакытта бик юмарт китерер җимеш.* Г.Тукай. *Бәя һәрвакытта бер, тәгаен була ул.* Ә.Еники

**ҺӘ́РВАКЫТТАГЫ** *с.* Гадәттәге, һәрвакыт була торган, даими. *Минем һәрвакыттагы хакимем – вөҗданымдыр.* Г.Исхакый. *Низами, һәрвакыттагы кебек, бүген дә иң башлап сөйгән кызы Зөбәйдәне исенә төшерә.* Г.Әпсәләмов

**ҺӘ́РВАКЫТТАГЫЧА** *рәв.* Һәрвакыт була торган шикелле, гадәттәгечә; моңа кадәр булган кебек үк. *Әнкәсенең*

*җылы йомшак кулы малайга һәрвакыттагыча гипноз шикеллерәк тәэсир итте.* А.Тимергалин. *Һәрвакыттагыча, безнең халыкка хас самими сөйләшүаңлашу, бер-береңнең йөрәк җылысын бүлешү.* Б.Рәхимова

**ҺӘ́РДАИМ** *рәв.* Даимән, һәрвакыт, гомер-гомергә. *Тарих фәне һәрдаим хакыйкатькә омтылырга тиеш, юкса аның беркем өчен дә кадере калмаячак.* М.Хәбибуллин. *Ә ябай халык исә сәетләрне хакимнәрдән һәрдаим өстен күргән.* В.Имамов

**ҺӘ́РДӘМ** *рәв. иск. к.* **һәрвакыт**. *Файда нә, дуслар һәрдәм мине мәдех итсәләр?* К.Насыйри. *Һәм түшәмнән һәрдәм тамчы коела.* Р.Зәйдулла

**ҺӘ́РЗАМАН** *рәв. к.* **һәрвакыт**. *Һич исәп юк, бездә бик мул аш та су, Һәрзаман күрнеп тора артып ташу.* Г.Тукай. *Сәгыйдьнең Галимәгә шул дәрәҗә мәхәббәте багланган, аңа гыйшкы шул дәрәҗәгә ирешкән иде ки, ул һәрзаман Галимәне үз күзе алдында тотасы килә, аннан аз гына да аерылырга риза түгел иде.* Г.Ибраһимов

**ҺӘ́РКАЙДА** *а.* Бөтен җирдә, барлык урында, теләсә кайда. *Халык күбен күп тә, көтүче белән игенчеләр аздыр, күрәсең. Һәркайда бер үк проблема...* З.Мифтахов. *Һәркайда бер – Җирнең сабыйлары, Тик өлкәннәр генә төрлетөрле!* Зөлфәт

**ҺӘ́РКАЙДАН** *а.* Төрле җирдән, бөтен яктан. *Кечкенәдән үк әнисе һәрбер кешедән шикләнергә, һәркайдан начарлык кына көтеп яшәргә өйрәтте аны.* Ф.Яруллин. *Ул бәйрәмнәргә һәркайдан, хәтта шәһәрләрдән дә бихисап халык җыела иде.* Р.Мирхәйдәров

**ҺӘ́РКАЙСЫ** *а.* 1) Телгә, искә алынган, сүз барган кешеләр, затлар барысы да аерым-аерым; һәркем. *Бүлмәләрдә дә кешеләр мәш килә, берсе дә Яңгурага күтәрелеп карамый, һәркайсы үз эше белән мәшгуль.* Г.Әпсәләмов. *Һәркайсы... табиб, шәфкать туташы, икътисадчы, укытучы, эшмәкәр буларак туган районы халкына хезмәт итә, берсе дә бәхет эзләп читкә китми.* В.Галиев

2) Һәрбер, теләсә нинди, бер ишләрнең арасыннан берсе булган. *Һәркайсы мәктәп Мәгариф министрлыгы хисабында булырга тиеш.* Г.Баруди

**ҺӘ́РКАЙЧАН** *рәв. к.* **һәрвакыт**. *Аяктагы итек һәркайчан көзге кебек ялтыраган була.* Г.Ибраһимов. *Минем уемча, аларга һәркайчан таянырлык иде.* А.Шамов

**ҺӘ́РКАЙЧАНДАГЫЧА** *рәв. к.* **һәрвакыттагыча**. *Ул (Әхнәф Садыйков) һәркайчандагыча әйбәтләп кырынган, шунлыктан иякләре күмкүк.* С.Рафиков

**ҺӘ́РКАЮСЫ** *а. иск. к.* **һәркайсы**. *Шүрәле авылында кыш урталарында, январь аенда, кич сәгать тугызда аяз, ай яктысы, фонарь кеби, авылның барча урамнарыны бик ачык күрсәтә; агачлар исә һәркаюсы һаваның суыклыгыннан хәбәр бирә: каюсы чарт, каюсы чырт дип кычкырып җибәрә ---.* З.Һади. *Ятимнәрнең һәркаюсы үзенең «исендә калганнар»ын озын-озак иттереп яза ала, әмма һәр Апуштан Тукай чыгалмый.* А.Тимергалин

**ҺӘ́РКЕМ** *а.* Һәрбер кеше, кем генә булмасын, теләсә кем. *Һәркемнең үз хөкеме.* Ә.Еники. *Бу бит авыл, монда һәркем күз алдында, бернәрсәне дә яшереп булмый...* Аманулла

**ҺӘ́РКӨНГЕ** *с.* Көн дә була (чыга, күренә) торган. *Димәк, җир читенә төшкән кызыл кояш урынына балкыр безнең өйләрдә икенче кояш – безнең һәркөнге кичке аш – икмәк.* Ш.Мәхмүдов. *Һәркөнге гәзит, радио, телевидение материалларына игътибар итик.* М.Гайнетдин

**ҺӘ́РНӘРСӘ** *а.* Һәрбер нәрсә, теләсә нинди әйбер. *Үтеп киткән назлы кыз чакны Һәрнәрсәгә бәйләп, нечкә күңел Ник сагына икән бу чаклы?..* К.Булатова. *Урманда Зурколакка һәрнәрсә кызык тоелган.* С.Сәүбәнова

**ҺӘ́РНИ** *а. к.* **һәрнәрсә**. *Хәер, бу табигатьтәге һәрни безгә бакый күк.* Г.Морат. *Монда һәрни сине көтә, Кайтырсың бер, түзмәссең, дип.* Р.Гарифуллина

**ҺӘ́РНИКАДӘР** *а. иск.* Теләгән кадәр, бернинди чиксез, күпме генә булмасын. *Ялганчылык белән аты чыккан кеше һәрникадәр тугры сүз әйтсә дә, ышандырмайдыр.* К.Насыйри. *Һәрникадәр госманлы шивәсене сөйсәм дә вә һәрникадәр төрекләрнең эшләнмеш вә фәсыйхләнмеш шивәләренә охшатып язуны йиңелрәк күрсәм дә, Казан төрекләренең лисаны әдәбиләре өчен аны кабул итмәк фикерендә түгелмен.* Һ.Максуди

**ҺӘ́РНИЧЕК** *а. иск.* Ничек кенә булса да, теләсә ничек, теләсә нинди юл белән. *Ни күрсәм дә күргәнмен, ни булса да булган – һәрничек мин бу гаиләгә сыймаганмын.* Г.Тукай. *Бу бер көн менлага бик озын тоелды, һәрничек булса да шәһәрдә йөреп, базарга, кибетләргә чыгып, көч-бәла илән бу көнне уздырды.* М.Акъегет

**ҺӘ́РТӨРЛЕ** *а.* Төрле-төрле, теләсә нинди, күп төрле; бөтен, барлык. *Үзешчән сәнгатьне төрле яклап үстерү, аңа һәртөрле ярдәм күрсәтү – безнең изге бурычыбыз.* Р.Вәлиев. *Әйе, ул язда һәртөрле вакыйгалар күп булды.* Р.Мирхәйдәров

**ҺӘРХӘЛДӘ** *рәв.* **1.** Шартлар нинди булса да, тәгаен, мотлака. *Зиннур һәрхәлдә килеп өлгерергә тиеш иде*

**2.** *кер. сүз. функ.* 1) Ничек кенә булмасын; бернәрсәгә карамастан, алаймы, болаймы. *Һәрхәлдә, әтиебез кайтып, әйдәгез, үз яныма алып китәм мин сезне, димәде, хат язып та чакырмады.* К.Миңлебаев

2) Әйтелгән сүзнең шиксезлегенә ышанычны белдергәндә кулланыла; һичьюгы. *Бәхетле булырга бернинди дә каршылык юк, димәк. Һәрхәлдә, юк кебек.* К.Тинчурин. *Шәлперәеп төшкән карт, ди, ректор, көч ягыннан минем белән ярыша алмый, һәрхәлдә.* Ш.Алпар

**ҺӘ́РЧАК** *рәв. к.* **һәрвакыт**. *Тик шуны яхшы беләм: Сырхау һәрчак читтә йөри, Дус булсаң чаңгы белән.* Л.Лерон. *Халык арасыннан чыккан талант һәрчак гади һәм кешелекле.* Р.Фәйзуллин

**ҺӘ́РЧАКНЫ** *рәв. к.* **һәрвакыт**. *Шул, шул, соңгы сүзне әйтүе һәрчакны катлаулырак.* З.Мәхмүди

**ҺӘ́РЧАКТА** *рәв. к.* **һәрвакыт**. *Без, исәннәр, Ватан сугышында гомерләрен биргәннәр алдында гаепле сыман – тере тормышта һәрчакта да лаеклы яши алмыйбыздыр.* Ш.Галиев. *«Дело»ларга һәрчакта да дөресе генә язылса икән....* М.Маликова

**ҺӘ́РЧАКТАГЫ** *с. к.* **һәрвакыттагы**. *Казан аэровокзалы перронында нәни флаглар белән һәрчактагы кебек каршы алучылардан берәү дә күренми.* Р.Ибраһимов. *Әнәс Тумашевның тормышы иҗат белән үрелеп бара. Кайда гына хезмәт куймасын, башкарган рольләре сыйфатлы һәм һәрчактагы кебек кызыклы иде.* Шәһри Казан

**ҺӘ́РЬЮЛЫ** *рәв.* Һәр очракта, һәрвакыт. *Конструктив әңгәмә нәтиҗәсендә һәрьюлы билгеле бер теоретик һәм практик нәтиҗәләргә дә ирешү күзәтелә.* Ялкын. *Дошман үзенең позицияләрен кире кайтарырга омтыла, өч тапкыр контратакага ташланып карый, ләкин һәрьюлы кире чигенергә мәҗбүр була.* Мәдәни җомга

**ҺӘ́РЬЯКЛАП** *рәв.* 1) Төрле яктан, һәр тарафтан. *Артта янә шул шау чәчкәле шомырт куагы. Кортларга шул гына кирәк тә: һәрьяклап сырып алалар.* К.Җәмит. *Гүя шушы ак тәлгәшләр кызны һәрьяклап уратып алган.* З.Мурсиев

2) Мөмкин булганча, төрле юллар белән. *Айсылу һәрьяклап аларның күңелен табарга тырыша.* Г.Бәширов. *Төрле фән өлкәләреннән татарча дәреслекләр төзүне һәрьяклап хуплау тиеш.* А.Тимергалин

3) Бөтен нечкәлекләрен дә игътибарга алып, җентекләп. *Әмер бирү генә җитми. Әйткәнеңне һәрьяклап күзаллый белү дә кирәк.* Н.Хәсәнов. *Күренекле әдип Фәтхи Бурнашның иҗаты әле һәрьяклап өйрәнүне көтә.* М.Шабаев

◊ **һәрьяклап килгән** 1) Бөтен ягы белән җитеш; барысы да җиренә җиткереп эшләнгән. *Дөньяда бер чибәр, һәрьяклап килгән, балкып торган хатын иде бит аның сеңлесе.* Р.Габделхакова; 2) Булдыклы, уңган. *Бар бит һәрьяклап килгән, талантлы кешеләр!* Ә.Салах

**ҺӘ́РЬЯКЛЫ** *с.* Нәрсәнеңдер төрле ягын, бөтен нечкәлекләрен эченә ала торган; күпьяклы, күпкырлы. *Россиядә ислам диненең асылын, йогынтысын һәрьяклы, комплексны һәм объектив өйрәнү әһәмиятле зарурилык булып тора.* М.Хәсәнов. *Әгәр дә башка халыклар безгә һәм читтәге татарларга әйбәт мөнәсәбәттә булсын дисәк, үзебездәге азсанлы халыкларга һәрьяклы ярдәм итәргә тиешбез.* Р.Миңнуллин

**ҺӘ́РЬЯКТАН** *рәв. к.* **һәрьяклап**. *Әхлетдин бабай Асияне мактарга тотынды: – Һәрьяктан булдыра торган уңган кыз, – диде.* Г.Әпсәләмов

◊ **һәрьяктан җитеш** *к.* **һәрьяклап килгән**. *Әгәр дә без яраткан Равил Шәрәфи һәрьяктан җитеш, тормыш шартлары уңайлы, гөлбакчадай бер капиталистик илдә яшәсә?* Ф.Мөслимова. **һәрьяктан килгән** *к.* **һәрьяклап килгән**. *Һәрьяктан килгән шушы кешенең дә бәхете булмасын инде, я...* М.Хуҗин

**ҺӘ́С-ҺӘС** *ы.* Сарык куганда яки чакырганда кулланыла. *Киребеткән кешеләргә «сарык» диләр, ни гаҗәп. Ник малларны кимсетәбез? Ялгышабыз, җәмәгать! Алар бездән тәртиплерәк, Эндәшсәң җаен табып, «Тәчтәч!» дисәң килеп җитә, «Һәс!» дисәң, китә чабып...* И.Гыйләҗев. *Ирек көлеп артка карады: – Фас түгел, һәс диген син аңа, мәхлук сарыкка.* Р.Кәрами

**ҺӘҮ** I *иярт. к.* **һау**. *Кайтабыз, кар – шыгырт-шыгырт, шыгырт-шыгырт, дуслар – уф-ых, уф-ых, эт – һәүһәү, һәү-һәү.* Г.Мөхәммәтшин

**ҺӘ́Ү** II *ы.* Сыерны чакырган, куган, тынычландырган вакытта әйтелә. *– Һәү, һәү... Кил, Бөйрәкәй, әйдә, мә! – Бөйрәкәй үзен әйдәгән Мәдинә артыннан күндәм генә иярде, күп тә үтми, чиләккә, зың-зың, чыж-чыж килеп, ак агынты агыла башлады.* Т.Гарипова

**ҺӘҮДӘҖ** *и. гар.* Дөя, фил кебек менге хайваннарның аркасына куела торган, еш кына һәр ягы бөркәүле утыргыч; михәффә, паланкин. *Гаишә һәүдәҗен күтәрә торган кешеләр, һичбер уйламастан, һәүдәҗне дөянең өстенә куйдылар, Гаишәнең анда юклыгын сизмәделәр дә.* С.Бикбулат

**ҺӘҮКӘШ** *и. фар. диал. ирк.* Сыер, түгәнәй. *Һәүкәш кайтып керде, Ачылган капкага чак сыеп.* А.Хәлим

**ҺӘФТӘ** *и. фар. иск.* Атна. *Габдулла әфәнде Петербургтан 2–3 һәфтә соңра әйләнеп тә кайтты.* Х.Зәбири

**ҺӘФТИЯК** *и. фар. дини* Коръәннең еш укыла торган сүрәләрен, аятьләрен үз эченә алган китап; әфтияк. *«Әлифби»не дә, «Әбҗәд»не дә ятлыйсың, кыш буена «Ясин»нең дә «башына җитеп», «Һәфтияк»кә дә «төшәсең»...* Г.Бәширов

**ҺӘ́-ҺӘ** *иярт. к.* **he-he**. *Фәтхерахманның шатлыгыннан йөрәге котланып: – Алаймы, һә-һә-һә! – дип көлеп җибәрде.* К.Тинчурин. *– Һә-һә-һә, мин котылдым, әл-лә-ләү, – дип, кулын чәбәкли-чәбәкли кеткелдәде каенсеңел.* Н.Гыйматдинова

**ҺӘ́-ҺӘ-ҺӘЙ** *ы.* Еракта торган кемне дә булса чакыру, ерактагы кемгәдер эндәшү сүзе. *«Һә-һә-һәй!» – дип аваз салган иде, Кырлар җавап бирде, болыннар.* Ф.Яхин

**ҺӘШ** *ы. фар.* Терлек-туарны, гадәттә сыер малын куганда әйтелә. *Көтүче: – Әйдәгез, сарыкларым, китте башыгыз. Олы абзардан кече абзарга. Һәш, һәш!* Татар балалар фольклоры. *Нәгъләт! Сыер булса – «һәш!» дияр идең, сарык булса – «төррә!» дип, эт булса – «чәбә!» дип, кәҗә булса – «кәҗә ристан!» дип кычкырыр идең! Дуңгыз бит, чучка!* М.Әмир

**ҺЕ** *ы.* 1) Гаҗәпләнү, шикләнү, ышанмау, аптырау хисләрен белдерү өчен кулланыла. *[Әпрәй:] Һе, шулаймы, Биктимер абзый?* А.Алиш

2) Килешмәү, кабул итмәү, яки, киресенчә, канәгатьлек, җиңелчә горурлык хисләрен белдерү өчен кулланыла. *Һе, йоклатырсың Хәйрук абзаңны [каравылда торганда], мамык түшәктә генә йокларга ярата ул.* А.Алиш

3) Ирония, җиңелчә шаяртуны белдерү өчен кулланыла. *[Ләлә:] Синеке дә билгеле! Һе, акыллы баш! Классыгыз белән китмәс өчен, таныш врачларыңнан справка җыеп йөргәнеңне белмиләр, ди.* А.Гыйләҗев

**ҺЕЙ** *ы. к.* **һай**. *Һей, туган, ул көннәрдәге хәлләрне искә алганда, хәзер дә аркалар чымырдап китә әле!..* В.Нуруллин. *Һей, абзый! Гармун ал!* И.Юзеев

**ҺЕМ** *ы.* 1) Нәрсәнедер әйтергә кыенсынып торуны яки базмауны белдерә. *Һем... Шулай бит ул авыру дигәнең: бүген исән, ә иртәгә аяктан ега.* А.Алиш. *Фәннур әле бусын уйлап бетермәгән иде. – Һем... – дип тәртелеп калды ул.* А.Гыймадиев

2) *к.* **he**. *Әмма картның хөкеме әллә кайчан ук әзер икән: – Һем, тапкансың укыр китап! «Хуҗа Насретдин»! Укыйсың икән, саваплысын укырга кирәк.* Г.Бәширов

**ҺЕМЛӘ́Ү** *ф. сөйл.* Еш-еш «һемһем» итеп тору

**ҺЕҺ** *ы. к.* **he**. *Һеһ, хәтер инде ул – төпсез иләк. Сиксәннән ашкан адәмнән әллә ни көтмә.* Ә.Баян. *Һеһ, ансат булса, үзең язып кара сатирик әсәр!* А.Фәләх

**ҺЕ́-ҺЕ** *иярт.* Җиңелчә генә көлеп кую тавышын белдерә. *И, шәп булды... Һе-һе-һе! Корбаннарыңны җый инде хәзер су төбеннән!* Ф.Абдуллин. *– Һе-һе, – дип көлемсери әтисе. – Карарбыз, азрак күзең ачыла башласын әле.* Р.Вәлиев

**ҺЕ-ҺЕ-ҺЕЙ** *ы.* 1) Еракта торган кемне дә булса чакыру, ерактагы кемгәдер эндәшү сүзе; һә-һә-һәй

2) Тезмә әсәрләрдә иҗек санын тутырыр өчен ялгый торган музыкаль фраза буларак кулланыла. *Һе-һе-һей! Кайчакта патшалар миннән Энҗе җыйдырса көчләп, Патша да юк, ил таркалды, Мин исән икән нишләп? Һе-һе-һей! Кая булдылар икән, дим, Минем җыйган энҗеләр?* А.Хәлим

**ҺИ** *ы.* 1) Көтелмәгән хәлгә гаҗәпләнү, аптырап калу яки соклану, канәгатьлек хисләрен белдерү өчен кул-

ланыла. *Һи-и... Бөтенләй өлгереп, ир-егет булып кайткансың, димме...* Г.Гыйльманов. *Һи, сине, тфү, тфү, күзләрең!..* Г.Бәширов. *Һи-и-и, Алланың бирмешe, нинди матур иртә.* А.Гадел

2) Шелтәләү, ризасызлык һ.б.ш.ны белдерә. *Һи, әле тиз генә буласың юк икән.* Г.Камал. *Һи, мактанчык! Бик исем китә. Андыйларны гына мин үзем дә беләм инде.* Г.Бәширов

3) Ис китмәү, борчылмауны белдерү өчен кулланыла. *Хәйләкәр карт чыпчык күзен дә йоммый җавап бирде: – Һи, апай, аның берние дә юк, бер гармунны яндырып, шуның көлен ашасаң, уйныйсың да китәсең.* Н.Әхмәдиев. *Һи, ярты сәгать кенә түзәргә була!* К.Кәримов

**ҺИБӘ** *и. гар. иск.* Бүләк, түләүсез бирелгән нәрсә. *Гакыл дигәнемез – Хак Тәгаләнең ихсаны вә гатасыдыр, вә һибәседер.* К.Насыйри

**ҺИБӘ ИТҮ** *ф. иск.* Бүләк итеп бирү. *[Ишан:] Шуннан соң әлеге ак күгәрченне күрсәтеп, әнә шул күгәрченне ишан хәзрәтенә, ягъни мәсәлән, мине күрсәтеп, шушы әүлия бәндәгә тотып һибә итеп бир, диде.* К.Тинчурин. *[Габдулла Тукай] Милләтенең яшь буыннарына бетмәс-төкәнмәс зур бер дәүләт һибә итеп, дөньядан кичте.* Г.Рәхим

**ҺИБӘ́ КЫЛУ** *ф. иск. к.* **һибә итү**. *Аннан соң Гантәр казыйга барып әйтте: «Ул бакча урынын мин мөселманнарга каберлеккә һибә кылдым, ул җир каберстан булсын», – диде.* К.Насыйри. *Сез үзегез хәзер зур булыңыз, вак-төяк мәсьәләләрне онытыңыз, бөтен кечкенә мәнфәгатьләрегезне, урам мәнфәгатьләрегезне алдымыздагы эшемезнең зурлыгы намена һибә кылыңыз.* Г.Исхакый

**ҺИДАЯТЬ** *и. гар.* 1) Туры юлны күрсәтү, хакка өндәү. --- *мәрхүм шәригате исламиягә бәни адәмне кысарга һәм тыгызларга килгән мәҗбүри бер карарнамә дип карамый иде, бәлки һидаять вә ислах илә галәмнең дөнья вә ахирәт, рәхәт вә сәгадәт арттыру өчен килгән нәсыйхәтнамә дип карый иде.* Һ.Максуди

2) Туры юл, хак юл; мөселманлык, ислам. *Озын сүзләрдән соң Муса әфәнде: «Мин аларны һидаятькә киләләр дип ышанам. Мин Фатих әфәнденең шул эше гөнаһын йолыр өчен эшләү дип беләм», – диде.* Г.Исхакый. *Һидаять юлына күндереп турайтам, дип көч түкмә, яраткач-яраткач, кәкре-бөкре килеш ярат, Йосыф!* Н.Гыйматдинова

**ҺИДАЯ́ТЬ ИТҮ** *ф. дини* Туры юлны күрсәтү; туры юлга чыгару. *Аллаһ безгә дә, сезләргә дә һидаять итсен.* М.Әмирханов

**ҺИДАЯ́ТЬ КЫЛУ** *ф. дини к.* **һидаять итү**. *Аллаһы Тәгалә, Адәмнең тәүбәсен кабул итеп, һидаять кылды.* К.Насыйри

**ҺИҖРӘТ** *и. гар.* 1) Бер урыннан икенче урынга күчү, күчеп китү; төпләнеп яшәр өчен башка урынга китү; эмиграция. *Бу кузгалыш моңарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән һиҗрәткә тиң иде.* Ф.Сафин

2) *тар., дини* Мөселманнарда ел исәбе башы булып саналган Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәккәдән Мәдинәгә күчеп китүе. *Ләкин һиҗрәттән алтынчы гасыр ахырларына кадәр хатыннар һаман да ирләр белән катышалар иде.* Г.Буби. *Һиҗрәттән сон тугыз йөз илле ел узгач булды бу хәл.* Р.Батулла

**ҺИҖРӘ́Т ИТҮ** *ф.* Күчеп китү, туган яктан читкә китү. *Рәсүлуллаһ һиҗрәт иткәннән соң, Әбү Ләһәб Сүвәйбәне азат иткән.* А.Тимергалин. *Унбер кеше ир затыннан, дүрт кеше мөслимәләрдән Хәбәш җиренә һиҗрәт иттеләр.* Ф.Яхин

**ҺИҖРӘ́Т КЫЛУ** *ф. к.* **һиҗрәт итү**. *Малларын-туарларын саттылар, җиһазларын, әсбабларын тараттылар, өем-өем кеше сәфәргә китә башлады – һиҗрәт кыла башлады.* Г.Исхакый. *– Күчмән Казан татарлары Төркиягә солтан Габделхәмит заманында һиҗрәт кылган, – диде Хәйдәр абзый.* Т.Әйди

**ҺИҖРИ** *с. гар.* Тарих башы буларак һиҗрәтне (*2 мәгъ.*) кабул иткән. *Бүген Болгар һиҗри белән 618, миладИ белән 1221 елга аяк басты.* М.Хәбибуллин. *Яңа гасыр туды. Һиҗри белән ундүртенче генә булса да, миладича егерменче булыр – Кешелеккә яңа бусага.* Р.Фәйзуллин

**ҺИЛАЛ** *и. гар. иск.* Яңа туган айның урак шикелле хәле; яңа туган ай. *Ул кылыч борны һилалдай, кашлары керпекләнеп – Җир йөзенә мөшәһкәнә биш нур чәчәр бөртекләре.* Г.Харис. *Яңгырамый инде азан, аһ, ауды ислам мөнбәре, Ак Һилал төште, киселде изге ак таң өннәре.* Б.Мирзанов

**ҺИММӘТ** *и. гар. иск.* 1) Ярдәм, булышлык, ихсан. *Мәктәпме, мәдрәсәме, җәмгыяте хәйрияме, башка нинди дә булса бер тәрәккый вә мәдәният эшеме – һәммәсе-һәммәсе байларымызның һиммәте белән генә бара!..* Г.Ибраһимов. *Җәмгыятькә ошбу һиммәт ияләренең иганәләр тапшырылды.* Һ.Такташ

2) Тырышлык, гайрәт, энергия, нәрсәгәдер салынган көч. *Барлык һиммәтләрен, һәммә гайрәтләрен трахтирларда, мәйханәләрдә генә күрсәткән байлар, халыкны һәртөрле чирмеш, керәшен сүзләренә Коръәннән артык иман китерткән карчыклар, өшкерүче-төкерүчеләр, – һичберенең үз башын коткарырга чарасы булмаганлыктан, бер-берсеннән ярдәм теләргә мәҗбүр булырлар.* Г.Тукай. *Кояшның кайралган кылычтай үткер нурлары ишекнең калҗайган такталары арасыннан сирпелеп, болай да күзсез келәт эчендәге караңгылыкны тагын да куерткан һәм андагы бар байлык, бар дәүләтне аерым бер илһам, аерым бер һиммәт белән тураклап ташлаган сыман.* А.Хәлим

3) Намус, абруй, дәрәҗә. *Олылык бишмәт белән түгел, һиммәт белән.* Мәкаль. *Ир кешегә һиммәт дигән нәрсә кыйммәт.* М.Гафури. *– Хуш, – диде Алмас, чын уен бик тирән яшереп, – мөселман кардәш һиммәте өчен тагын бер тырышып карыек булмаса – үз өстемезгә бик зур мәсьүлият алып, Мусаны үзебезгә җибәрүләрен үтенеп, Шәрык министрлыгына чын күңелдән шикаять языек.* Г.Әпсәләмов

**ҺИММӘ́Т ИТҮ** *ф. иск.* Тырышу, көч салу; ярдәм күрсәтү. *Бинаән галәйһи һәрничек җәмгыяте хәйриянең суммасын күбәйтергә, моннан соңра садакаларның урынсыз җирләргә акмавына һиммәт итәргә кирәк.* Г.Тукай. *Һәм динебезне – ислам динен куәтләндермәккә һиммәт итик!* Тәхризнамә

**ҺИММӘ́Т КЫЛУ** *ф. иск. к.* **һиммәт итү**. *Аннан соң Мурашкин дигән авылда Ибрами исемле бер кеше, һиммәт кыйлып, Сары күл ярминкәсен яңартты.* К.Насыйри

**ҺИММӘТЛЕ** *и. иск.* 1) Ярдәмчел, киң күңелле, ихсанлы, булышырга әзер булган. *[Себер бае:] Афәрин, афәрин, сездә дә шундый һиммәтле яшьләр бар икән.* Г.Камал. *Менә хәзер Зәйнулла ишан хәзрәтне сөйгән, олуглаган һиммәтле байларның вазифасы – шул мөкатдәс хезмәткә акча табу.* Г.Исхакый

2) Дәртле, гайрәтле, тырыш, энергияле. *Шуның өчен ирләрне һиммәтле вә фазыйләтле кыласың килде исә, иң элек хатыннарга һиммәт вә фазыйләт,*

*гайрәт вә диянәт үрәтергә кирәк.* Г.Буби. *Күп иде алар. Ачык карашлы, үткен хисле, ялкынлы күңелле, укуга бирелгән, халыкка хезмәткә чыныннан дәртле, һиммәтле вә өмидле егетләр...* Г.Ибраһимов

3) Намуслы, абруйлы, дәрәҗәле; хөрмәт ителгән, могтәбәр. *Таза, куәтле тәннән тышкы авырулар тиз арада юк булган кебек, Һаҗәр тирәсенә уралган гайбәтләр дә, бара торгач, үзеннән-үзе беттеләр, югалдылар. Ул – һиммәтле, атаклы Кадыйр байның бикәсе...* Г.Ибраһимов. *Ләкин һиммәтле, затлы икәнемне мин бервакытта да онытмадым.* Д.Каюмова

**ҺИММӘТЛЕЛЕК** *и. иск.* Һиммәтле булу сыйфаты. *Татар арасындагы зиһенлелекне, аңлылык һәм һиммәтлелек дәрәҗәсен күрегез!* Ш.Мәрҗани

**ҺИММӘТСЕЗ** *с. иск.* Тар күңелле, каты, рәхимсез; түбән; намуссыз; һиммәте булмаган. *Хәкимнәр әйткән: бәкләрдә һич дуслык юктыр, ялганчыларда вафа юктыр, көнче кешеләрдә рәхәт юктыр, һиммәтсез кешедә мөрәүвәт юктыр, яман холыклы кешеләрдә олуглык юктыр.* К.Насыйри

**ҺИММӘТСЕЗЛЕК** *и. иск.* Һиммәтсез булу сыйфаты, каты күңеллелек. *Бу күз яшьләренә --- шул һәйәте иҗтимагыяләрнең һиммәтсезлеге вә инсаниятсезлеге сәбәптер.* Г.Тукай

**ҺИММӘТЧЕЛ** *с. иск. к.* **һиммәтле**. *Әлмәт шәһәреннән Лилия Тәхаутдинова, залны төзекләндерүгә илһам биргән һиммәтчел шәхесләрнең берсе, кадерле укытучыларына сәхнәдән баш иде.* Бөгелмә авазы

**ҺИНД** *и. гар.* 1) Һиндстанда яшәүче төп халыкның атамасы һәм шул халыкның бер кешесе; индус. *Өсләренә ефәк белән елык-елык итеп кенә торган атлас киемнәр киеп йөрүче, энҗедәй ак тешле, йолдыздай үткен күзле, кызыл я кара тәнле һиндләр, гарәпләр, кытайлар, тагын әллә кемнәр!* Г.Бәширов. *[Габдрахман:] Башка кинолар беткәнмени суң?! [Мөхәммәтхан:] Бар. Ләкин ул тавышсыз совет киноларына беркем дә килми. План үтәлми. Ә һинд киносына бөтенесе өерелеп килә.* Г.Каюмов

2) Һиндстан. *Бу гарәп дәүләте – гарәп хәлифәсен үз мактанычы белән торгызып, үз яклавына алып, бөтен Гарәбстанның зур өлешләрен үз яклавында итеп, Мисыр һәм Һиндне тәэмин итәчәк.* Г.Баруди. *Элек Казанда лимон, әфлисун, һинд чәе ише нәрсәләр юк, Мәскәүгә барган һәр кешегә шуларны алып кайтырга кушып җибәрә идек.* Ф.Яруллин

**ҺИНД-ЕВРО́ПА** *и. махс.* Кайбер изафәле сүзтезмәләрдә килеп, «Көньяк Азия һәм Европа территориясендә тел уртаклыгы нигезендә берләшкән күпсанлы халыкларга караган» мәгънәсен белдерә торган сүз. *Киң таралган рәсми фән раслаганча, иң элек, янәсе, һинд-европа халыклары барлыкка килгән, алар аңлырак, мәдәнирәк булганнар.* Ф.Хатипов. *Һинд-европа телләре моннан 8–10 мең еллар элек формалашкан, дип уйланыла.* Н.Фәттах

**ҺИ́НД ЗӘГЪФРАНЫ** *и. бот.* Имбирчәләр семьялыгыннан тропик Азиядә, Төньяк Австралиядә, тропик Африкада үсә торган, тамыры һәм сабаклары эфир майларына, буяуга бай булган күпьеллык үләнчел үсемлек; куркума. *Куркума (Curcuma longa) яисә һинд зәгъфраны бик көчле антиоксидант санала һәм картаюга каршы көрәшнең дә иң үтемле ысулы икән.* Әлмәт таңнары

**ҺИНДИ́** *и. фар.* **1.** 1) Һиндстан халкыннан булган, һиндстанлы; һинд. *Җиргә Шәфәкъ йолдызыннан китерелгәнбез, оланнар. --- Башка халыклар Сириус дип йөртәләр үзен. Кытайлар, монголлар, һиндиләр үзләренчә атыйлар.* Г.Госман

2) Һиндстанның дәүләт теле, һиндустанинең ике (һинди һәм урду) әдәби формасыннан берсе; *русчасы:* **хинди**. *Һиндстанда рәсми телләрнең саны – 22. Дәүләт теле буларак һинди телен генә калдырырга маташканнар иде дә, башка телле өлкәләр моңа каршы чыкты.* Р.Батулла

**2.** *с. мәгъ.* Һинд халкына яки теленә караган; Һиндстанга мөнәсәбәтле. *Фарси Синдбад исеме һинди хәким Сиддхапати исеменнән килә.* А.Тимергалин. *Бу Хәбибулланың бер һинди ишәге бар иде.* Т.Ялчыгол

**ҺИНД-ИРАН** *и. махс.* Кайбер изафәле сүзтезмәләрдә килеп, «һинд-европа телләренең Көньяк Азия территориясендә тел уртаклыгы нигезендә берләшкән күпсанлы халыкларга караган» мәгънәсен белдерә торган сүз. *Һинд-иран һәм сугди алынмалардан фарсы-таҗик алынмалары яңа (IX–X гасырларда формалашкан) фарсы теленнән булулары белән генә аерыла.* Р.Әхмәтьянов

**ҺИНДИРАНЛЫ** *и.* Һинд-европа телләренең бер тармагында сөйләшә торган, башлыча Көньяк Азиядә таралып яшәгән халыкларның бер вәкиле. *Һиндиранлыларның яшәү ареалы*

**ҺИНДИ́ЧӘ** *рәв.* Һинди телендә. *Мин исә, сүгенерлек кенә булса да, һиндичә бераз сукалыйм.* А.Хәсәнов. *Робертино Лоретти – итальянча, Радҗ Капур – һиндичә, Роза Багланова – казакъча җырлап дан алдылар.* М.Латыйфуллин

**ҺИ́НД КАМЫШЫ** *и.* Бамбук. *Вәлиләр фатиры хәзер джунглины хәтерләтә: бөтен җирдә һинд камышлары үсеп утыра.* Ф.Зариф

**ҺИНДЛЕ** *и. ялг. к.* **һинд, һиндстанлы**. *Һиндле нәккашлар, әфгани, төрки рәссамнар, һурду осталары эшли монда.* Р.Батулла. *Һиндлеләрнең фәлсәфи тәгълиматын күп еллар дәвамында дини-мифологик концепция билгеләп килә.* К.Гыйззәтов

**ҺИНДОЕВРОПЕ́ЙСТИКА** *и.* Лингвистиканың һинд-европа телләрен чагыштырма-тарихи ысул белән өйрәнә торган тармагы

**ҺИНДО́ЛОГ** *и.* Һиндология белгече. *Һиндологлар конференциясе*

**ҺИНДОЛО́ГИК** *с.* Һиндология белән бәйле, шуңа мөнәсәбәтле. *Һиндологик үзәк*

**ҺИНДОЛО́ГИЯ** *и. фар.-гр.* Һиндстан мәдәнияте турындагы фәннәр җыелмасы. *Хәзерге һиндология казанышлары*

**ҺИНДСТАНЛЫ** *и.* Һиндстанда туып үскән, шунда яшәүче; Һиндстан кешесе. *Тукай җирдәге зобаниларны тәнкыйть иткәндә дә, һиндстанлыларны кылычтан кичергән, ачлык белән каһәрләгән инглизләрнең колониаль сәясәтен искәртеп китә.* Д.Абдуллина

**ҺИ́НД СҮСЕ** *и. бот.* Юкәчәләр семьялыгыннан кырыйлары теленмә овал яфраклы, сүсе җиһаз ясауда, техник тукымалар җитештерүдә кулланыла торган биек куак, ярымкуак һәм үләнчел берьеллык үсемлек; джут. *Русия бу илгә шулай ук арыш, карабодай һәм бал бирә ала, ә Бангладеш диңгез продуктлары, һинд сүсе, чәй китерергә әзерлеген белдерә.* Кызыл таң

**ҺИНДУ** *и. фар.* Индуизм динен тотучы (башлыча һинд), һиндуист. *Һиндуларның борынгы гыйбадәтханәләре*

**ҺИНДУИЗМ** *и. санскр.* Һиндстанда иң киң таралган дин: төп агымнары Вишну һәм Шива илаһларын олылауга

нигезләнгән; индуизм. *Хәзерге вакытта һиндуизмда, тантризмда, синтоизмда, кайбер Африка халыкларында фаллоска табыну яшәп килә.* А.Тимергалин. *Һиндуизм мифларына караганда, вафат булган индуска, күккә күтәрелер өчен, елга аша үтәргә туры килгән.* Шәһри Казан

**ҺИНДУИСТ** *и. фар.-гр. к.* **һинду**. *Бар бәндә дә мөселман булып тугач, каян килә соң христианнар, буддистлар, яһүдиләр, һиндуистлар һәм башкалар?* И.Әмирхан

**ҺИНДУС** *и. ингл. < фар. иск.* 1) Индус, һинд, һинд кешесе. *Һиндусларның инглизләрдән «үрнәк вә мәдәният алулары» турында, большевикларның һинд вә мисырлыларны «үз милләтләренә мөстәкыйльлек бирү белән мактанып алдаулары» турында моңынчы татар әдәбиятында мисле күрмәгән ялганнар языла.* Г.Исхакый. *Кытай сәүдәгәре ефәк тукымаларын мактый, һиндус кулында – асылташлар, рум кешесе затлы савытлары белән мактана, болгар үзенең болгари күнен җәеп салган, кыпчак чабыш атлары алып килгән...* Р.Зәйдулла

2) *иск.* Индуист, һиндуист. *Һиндуслар гыйбадәтханәгә җыелган*

**ҺИНДУСТАНИ** *и. фар.* Һиндстанда һинд теле, Пакьстанда урду теле дип аталган, ике стандарт язма формасы булган, Көньяк Азиядә милләтара аралашу өчен кулланылган һинд-европа теле. *Найда инглизчә сөйләшә ала. Пакьстанда аны хәтта күпләр һиндустани (урду) телен дә аңлый дип уйлый иделәр.* Й.Хәлиуллин

**ҺИНДУСТАНЛЫ** *и.* Төньяк Һиндстан (Һиндустан) территориясендә яшәүче, һиндуизм динен тотучы һиндарий халкының бер вәкиле

**ҺИ́НДЧӘ** *рәв.* **1.** 1) Һинди телендә. *Ватар – русча вода, немецча вассер, һиндчә уда сүзләренә якын.* Н.Фәттах. *Концерт бара. Хәмбәл һиндчә җырлый.* Р.Сәгъди. *[Мөхәммәтхан:] Мин үртәшмим. Һиндчә шулай була ул.* Г.Каюмов

2) Һиндләр кебек, шулар гадәтенчә. *Үзең уйлап кара: сүзе татарча, көе – этем белсен кайдан, башкару манерасы – һиндчә.* Л.Әбүдәрова. *Ә икенче көнне Санджайның апалары килеп, Светага сари кидерделәр һәм һиндчә бизәндерделәр.* Г.Сөнгатуллина

**2.** *с. мәгъ.* 1) Һинд телендә булган. *Һиндчә җыр*

2) Һиндләрдә булган, кулланылган. *Шуңа да карамастан, (Гомәр) ун яшендә инде грамматиканы, тел белеме теориясен, стилистиканы белә, һиндчә исәпләүгә, алгебра һем геометриягә күчә.* Җ.Ильясов

**ҺИ́НД ЧИКЛӘВЕГЕ** *и. бот.* Кокос. *Төшеңдә һинд чикләвеген ватсаң, фалчылар белән очрашырсың, сүзләрен ишетерсең, әгәр дә ашасаң, аларга ышанырсың.* Ф.Яхин

**ҺИНДЫБА** *и. гар. бот.* Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан ачык зәңгәр чәчәкле, каты сабаклы, киптерелгән тамырыннан кофе суррогаты алына торган ике яки күпьеллык үлән үсемлек; фәрештә чәчәге, цикорий, күнаяк, буынчәчәк. *Басу кырында зәңгәр чәчәк – һиндыбалар атынып утыра.* Р.Батулла. *Кара күзләрдә дә коелмый ул Кыр чәчәге – кыргый һиндыба.* Р.Сәйфетдинов

**ҺИНДЫБАЛЫ** *с.* Һиндыба катнаштырылган, составында һиндыба булган. *Һиндыбалы эчемлек*

**ҺИНДЬЕВРО́ПАЛЫ** *и.* Кардәш телләрдә сөйләшә торган Европа, Алгы Азия һәм Һиндустанда таралып яшәгән халыкларның бер вәкиле. *Һиндьевропалыларның сугыш кораллары усактан ясалган.* Р.Әхмәтьянов

**ҺИҺЕЛДӘ́Ү** *ф.* Һи-һи дип йомшак кына көлү. – *Соң... Хәзер генә белдеңмени әле аның чегән икәнен, – дип, әкрен генә һиһелдәде икенчесе.* Ф.Баттал

**һиһелдәп куюь** Бер тапкыр һиһелдәү

**ҺИ́-ҺИ** *иярт. к.* **һе-һе**. *Бер ярлы мәзин күмгәндер инде моны, мулласыннан яшереп. Ярминкәгә баргач яңа чалма белән чапан алып булмасмы, дип уйлагандыр, мескен, һи-һи-һи...* Г.Мөхәммәтшин

**ҺИЧ** *фар. рәв.* **1.** 1) Бөтенләй, бер дә. *Мин ант итәм синең каберењдә: Һич кызганмам явыз дошманнарны.* Г.Кутуй. *Ярар, без бит туганнар, уртак тел табу һич кыен түгел.* А.Хәсәнов

2) Беркайчан да, һичбер вакытта, мәңге. *«Әни» диеп язып куйдым Яңа яуган ак карга. Таптамагыз! Һич ярамый «Әни» сүзен таптарга!* З.Туфайлова

**2.** *а. мәгъ.* Бернинди, бертөрле дә; һичбер. *Яшибез: тормыш иркен, тормыш мул, һәммәсе шәп, һич ихтыяҗ юк, эчәр суны чишмәдән ташыйлар, сөт-каймак, итне авыл хуҗалыгы институтының фермасыннан китерәләр, беренче сортлысын гына ашыйбыз.* А.Гыйләҗев. *Әгәр шулай мөмкин булса, Сәкинәне һич икеләнүсез барып алып кайтыр идем мин.* В.Нуруллин

◊ **Һич булмаса** 1) Әгәр башка мөмкинлек булмаса, соңгы чара рәвешендә; ахыр чиктә. *Матур кыз, һич булмаса ахыр гомеремне ир белән үткәрим дип, агач таяк белән йөри торган сиксән яшьлек бер картка куана-куана барды.* Г.Тукай; 2) Ичмасам, хәтта. *Җир йөзендәге күз яше һич булмаса бер генә тамчы кимедеме?* Г.Ибраһимов. **Һич кенә дә** Бер дә. *Шунысы гаҗәп әле аның: чит тел, гәрчә укуны авырлаштырса да, бу очракта һич кенә дә киртә булып тора алмый.* С.Ибраһимова. *Моның ни мәзәге бар икән? Аны Галимҗан һич кенә дә башына сыйдыра алмый.* С.Поварисов. **Һич шөбһәсез** Бернинди икеләнүсез, катгый рәвештә; әлбәттә. *Җиткерәбез без аңар бер бик матур шатлык хәбәр: Алдагы көзгә арыш, һич шөбһәсез, булыр чибәр.* Г.Тукай. *Штат төзү өчен әһәмиятле шартлардан берсе кеше булса, икенчесе, һич шөбһәсез, икътисадтыр.* Г.Исхакый. **Һич (тә) юкка** Бер сәбәбе булмый торып; нигезсез рәвештә. *Хатын һич тә юкка бәйләнгән булып тавыш куптара...* А.Гыйләҗев. *Каһәрләмә намусыңны, Битәрләмә һич юкка. Син бит бары сулар сиптең Янып сүнгән учакка.* В.Фатыйхов

**ҺИЧ-** Кайбер кушма алмашлыкларда инкярны яки юклыкны белдерә торган беренче кисәк (мәс., *һичкем, һичкайчан, һичкайда, һичнинди* һ.б.)

**ҺИ́ЧБЕР** *а.* 1) Исемнәрдән алда килеп, шул исем белдергән нәрсәләр арасыннан берсе генә дә булмауны белдерә; берсе дә, бернинди, бертөрле дә. *Күршеләрне калдырма бүләксез һичберсен дә.* М.Мирза. *Шуннан соң аюлар турысында һичбер хәбәр ишетелмәде.* Гали Рәхим

2) Фигыльләрдән алда килеп, алар белдергән гамәлнең бер генә тапкыр да булмавын белдерә; һич, һич кенә дә, беркайчан да. *Әмма әгәр дә һичбер эчмәсәң, Аллаһы Тәгалә синнән разый булыр һәм халык арасында исемең олуг булыр.* К.Насыйри. *Иртәнге чык тамчылары белән Таң нурлары гыйшык уйныйлар. Бер-берсенә сөю бүләк итеп, Иркәләнеп һичбер туймыйлар.* К.Фатыйхова-Бәдртдинова

◊ **Һичбер сүзсез** Бернинди каршылыксыз, бәхәссез, шунда ук. *Олы бабам Ибраһим бит дустың иде, Әмереңә һичбер сүзсез башын иде,*

*Исмәгыйльне – углын – сиңа корбан бирде.* К.Гали. **һичбер хәлдә** Нинди генә шартларда булмасын, беркайчан да. *Театр һичбер хәлдә коры агитация урыны гына булып калырга тиеш түгел, ул бөек агитацион бурычларны үзенең специфик, сәнгатьчел чаралары белән үтәргә тиеш.* Ф.Бурнаш. **һичбер шик юк** Ап-ачык, бик билгеле, бәхәссез. *Ияр өстендә этәч сыман кукраеп утырган бу бәндә – Тимучинга Онон елгасын кичкән чакта очраган ут карашлы җайдак һәм, һичбер шик юк, ул мәркет бәгенең бик тә якын бер туганы иде.* В.Имамов

**ҺИ́ЧБЕРӘҮ** *а. к.* **һичкем**. *Башчыбыз – Таз, берзаман без уйнадык; Һичберәү күрмәс әле, дип уйладык.* Г.Тукай. *Шулай ук шәһәр йогынтысыдыр инде: Гомәрнең һичберәүдә булмаган ау мылтыгы да бар иде.* Ә.Еники

**ҺИ́ЧВАКЫТ** *а.* Һичкайчан, бервакытта да. *Көнләшәм биеклегеңә, Хыялың оча биек. Ул биеклеккә һичвакыт Меналмый җанвар-киек.* Н.Сафина

**ҺИ́ЧВАКЫТТА** *а.* **һичвакыт**. *Тегеякта тауда – ак чиркәүләр, Бу як ярда балкый мәчетләр. Язмышлардан узмыш юктыр инде, Һичвакытта булмыйк без читләр.* Р.Сәйфетдинов

**ҺИ́ЧЗАМАН** *а. к.* **һичкайчан**. *Кем йөртсә дә ул корабны, Ярга чыкмый һичзаман. Кораб бар кырык ямаулы. Корабка юк юламан.* Р.Харрасова

**ҺИ́ЧКАЙДА** *а.* Беркайда да, бер җирдә дә. *Һичкайда чыгу юк миңа, мин бу өйдә ябылып ятам.* И.Хәйруллин. *Мирсәет һичкайда ачылып китеп сәясәт хакында сүз кузгатмады әлегәчә.* Р.Мөхәммәдиев

**ҺИ́ЧКАЙДАН** *а.* Бернинди урыннан да, бер яктан да. *Мортаза бай йортның су көпшәләрен юри бикләтеп куйганлыктан, һичкайдан бер тамчы су табарга мөмкин түгел иде.* М.Галәү. *Бу чакта Казан иң уңайсыз хәлдә булып, аның һичкайдан ярдәм алу ихтималы юк иде.* Һ.Атласи

**ҺИ́ЧКАЙСЫ** *а.* Күп төрле нәрсәләрнең берсе дә. *Яуса да көчле давыллап яңгыр һәм дә кар, буран, Һичкайсы үчерә алмас кабынган утны дулап!* Т.Әйди. *Һичкайсыбыз рәнҗетелми һичбер кемнән – Без һәммәбез Аю дигән бер нәселдән.* Ә.Рәшит

**ҺИ́ЧКАЙЧАН** *а.* Һичбер вакытта, беркайчан, бервакытта да; бернинди шартларда да. *Җәнҗаллы өй һичкайчан да җитенке була алмый.* М.Хәсәнов. *Шушы назлы-үтенечле караш Сезгә генә булсын дисәгез, Сөйгән ярыгызны һичкайчан да Ялгызлыкка дучар итмәгез!* И.Сабиров. // Мәңге. *Бөек иҗат һичкайчан югалмый.* Г.Кутуй. *Синең бары җырлап бу дөньядан Китеп барган көнең, Тукайҗан! Чишмә җырлап, кеше елап туа, Җырлап киткән үлми һичкайчан!* Н.Сафина

**ҺИ́ЧКАЯ** *а.* Бернинди урынга да, беркая да. *Чирләү сәбәпле, һичкая чыкмыйча, өйдә генә ятарга туры килде.* Г.Кутуй. *Чынлыкта профессор һичкая ашыкмады.* Ф.Яхин

**ҺИ́ЧКЕМ** *а.* Бер кеше дә, бернинди зат та, беркем. *Бирмә сер һичкемгә: сөйләшсәң сөйләш өстән генә.* Г.Тукай. *Булат әмирнең әрнү-газапларын һичкем ишетмәде.* В.Имамов

**ҺИ́ЧНӘРСӘ** *а.* Берни, бернәрсә дә. *Әмма Зөбәер беркем белән дә аралашып китмәде, һичнәрсәгә катышмады, тулай торак, анда яшәүчеләр аңа әллә бар, әллә юк иде.* Д.Булатова. *Сөембикә Шәехгалине кан калтырап көтте. Кулларының хәле китте: һичнәрсә тормый, ике-өч затлы чынаякны да идәнгә төшереп ватты.* М.Әмирханов

◊ **һичнәрсәдән хәбәрсез** Бернәрсә белмичә, ваемсыз рәвештә. --- *Табигатьнең матур һәм аңгыра мәхлуклары – балыклар, һичнәрсәдән хәбәрсез, бертуктамый айга каршы сикерә, уйный иделәр.* Ш.Камал

**ҺИ́ЧНИ** *а. к.* **һичнәрсә**. *Минем баш шундый каткан, һични итәр хәл юк.* Г.Исхакый. *Мескен ана һични шәйләмәде.* В.Имамов

**ҺИ́ЧНИНДИ** *а.* Бертөрле дә, бернинди дә. *Балаларга исем бирү, өйләнү, мәетләрне күмүдә һәркем үз ихтыярында булып, моңа кем дә булса читтән катнашмаган, ягъни Россия дәүләте бу эшләргә һичнинди каршылык кылмаган.* Ш.Мәрҗани. *Кызның кашлары җыерылды, ләкин һичнинди кәефсезләнү сиздермәде.* Х.Камалов

**ҺИ́ЧНИЧЕК** *а.* Берничек тә, бөтенләй. *Кыз әле һаман да зәңгәр күзле шагыйрь егетнең каладан тиз генә, көтмәгәндә генә китеп баруын һичничек башына сыйдыра алмый.* Ф.Сафин. *Бу дөньяның даны, дәрәҗәсе Кызыктырмый мине һичничек.* Ф.Зыятдинова

**ҺИ́ЧӨЗЛЕКСЕЗ** *рәв. к.* **һичтуктаусыз**. *Хәзер шул унҗиде диңгез Күңелемне – йолдызларны үзенә тарта һичөзлексез!* Р.Гаташ. *Ә менә мәгълүм сәбәпләр аркасында бер кыйтгадан һичөзлексез икенчесенә йөреп торган араларда, үз милләтенең Салих Сәйдәшев, Фәрит Яруллин, Рөстәм Яхин кебек олуг композиторлары моңнарын җанына сеңдерә, белеп бетерә алмавы өчен, кинәт кенә аңа [Рудольф Нуриевка] бик уңайсыз һәм үкенечле булып китте.* Р.Вәли

**ҺИ́ЧСҮЗСЕЗ** *рәв.* 1) Каршылыксыз; бернинди каршылык күрсәтмичә, шунда ук; икеләнмичә. *Мәгәр бу өлкәдә миңа һичсүзсез буйсыну бетте: еш кына сүз көрәштереп, мин теләгән өтерне куйдырмый кала башладылар.* М.Яһудин

2) Бәхәссез, тәгаен, һичшиксез. *Хәлсез булсаң, бетәсең. Исән калу өчен көч тупларга кирәк. Шуңа күрә бүген безнең һичсүзсез үз дәүләтебез булырга тиеш.* Р.Вәлиев. *Әле болардан башка да истәлекле даталарыбыз күп. Әйтик, бу елны һичсүзсез Тукай елы дип атап булыр иде.* Р.Фәйзуллин

**ҺИ́ЧТӨРЛЕ** *а. иск.* 1) Һичнинди, һичбер төрле. *Мондый җавапсыз «тәнкыйтьләр» язучыга һичтөрле файда бирмиләр.* М.Җәлил

2) Берничек тә. *Хәзерге заманда мәдәни милләтләр арасында шулай тиз заман эчендә шөһрәткә менүче мөхәррирләр еш-еш чыгып торсалар да, аларны вә аларның шөһрәтен Тукаев вә аның шөһрәте белән чагыштыру һичтөрле мөмкин түгел.* Гали Рәхим

**ҺИ́ЧТУКТАУСЫЗ** *рәв.* Бер дә туктап тормыйча, өзлексез рәвештә, бертуктаусыз, берөзлексез. *Оҗмахның кызлары вә угланнары һичтуктаусыз оҗмах шәрабларыннан биреп торырлар.* К.Насыйри. *Һичтуктаусыз әрнеп-сызланып госпитальнең тимер караватында аунаганда, Бибисорурын, улы белән кызын күрәсе килеп үзәкләре өзелде.* Ф.Җамалетдинова

**ҺИ́ЧШИКСЕЗ** *рәв.* **1.** Һич икеләнеп тормыйча, һич шикләнмичә; тәгаен, бәхәссез. *Зөлмәт, йодрык сугышында үзен һичшиксез батыррак санаса да, шулай да ул үзенең серле тасмаларына ныграк исәп тоткан иде, ахрысы.* Н.Фәттах. *Сөен бәк! Матур исем. Ул һичшиксез баһадир булыр.* Р.Батулла

**2.** *кер. сүз. функ.* Әлбәттә, бернинди шөбһәсез. *Гади мәсьәләне хәл итү өчен бу ысул, һичшиксез, яраклы.* А.Тимергалин. *Көндәлек матбугатта басылган шигырьләрне күздән кичереп баручының, һичшиксез, үз фикере була,*

*андый укучыны берни дә юлдан яздыра алмый.* Б.Рәхимова

**ҺИ́ЧЬЮГЫ** *кис.* **1.** Үзе караган сүзнең мәгънәсен көчәйтү өчен кулланыла; аз дигәндә, минимум. *Хатын тарафыннан һичьюгы бер уч җылы өметләнгән очракта, иргә, мылтык асып, урман иңләргә кирәк иде.* Н.Гыйматдинова

**2.** *кер. сүз. мәгъ.* Һәрхәлдә, ничек кенә булса да, бернәрсәгә карамастан. *Һичьюгы, «янәшә» сүзе кулайрак булыр иде әле.* А.Тимергалин

**ҺИ́ЧЬЮГЫНДА** *кис. к.* **һичьюгы**. *Китапларың бармы, Равил, ручкаң, дәфтәрләрең бармы, дип сорамаса да, һичьюгында, килдеңме, дисә дә күңелең булыр иде.* В.Нуриев. *Кешем минем, мең гайрәтең чигеп Качкан чакта яшел тугайдан, Качкан чакта бу җимерек җирдән, Һичьюгында су эч курайдан...* Зөлфәт

**ҺМ** *ы. к.* **һем**. *[Назыйх:] Һм, Рамай аркасында бу кадәрле конфликт килеп чыгар, дип кем уйлаган.* З.Хәким. *[Сәрбиназ:] Һм-м, беләсең килә тагын үзеңнең!* А.Гыйләҗев

**ҺО** *ы. к.* **һу**. *Һо-о, безнең Шәйхулла да әйләнеп кайткан икән!* В.Нуруллин. *Кияүнең кәефе шәп иде, шуңа сөйләшүдән туктамады: – Һо, шактый саллы гына сумка күренә.* К.Кара

**ҺОМАЙ** *и. фар. миф.* Күләгәсе кемнең башына төшсә яки үзе килеп кунса, шул кеше чиксез бәхетле була, дип ышанылган бәхет кошы. *Һомай тоткандай, Әнисә белән елмаешып, мөзакәрә үткәреп, үбешеп утырасыз – үз башыңа азаланасың, әбәү!* В.Садыйков. *Бервакыт халык арасында «Һомай оча! Һомай оча!» дигән хәбәр таралган.* Г.Гыйльманов

**ҺОП** I *ы. к.* **һап** I. *Һоп итеп коймa аша бакчага сикереп төшим дигән идем, башыма саллы гына бер нәрсә килеп төште.* Ф.Яруллин

**ҺОП** II *иярт. к.* **һап** II. *Ул салган кармак очындагы селәүчәнне килеп каба. Һоп!.. Хәзер ул гүзәл җан иясе тау башында ялтырап ята.* Р.Мингалимов

**ҺӨДҺӨД** *и. гар. зоол.* Һөдһөдчәләр семьялыгыннан җилпәзә сыман ачыла алган зур бүрекле, озын гына томшыклы чуар кош; *русчасы:* **удод**. *Ул сүзләр бер колакка кереп алдыларммы, һич онытыласылары килмичә, авыз эчендә әвәләнә башлыйлар: һөдһөд, дөлдөл... төрҗәгун...* Г.Бәширов. *Төшеңдә һөдһөд кошын күрсәң, зур галим һәм ачык гыйлем иясе булырсың, диелә «Төхфәтел-мөлек» китабында.* Ф.Яхин

**ҺӨДҺӨ́ДЧӘЛӘР** *и. күпл. зоол.* Мөгезборын кошлар отрядыннан һөдһөдләрнең төрле төрләрен берләштерә торган семьялык; *русчасы:* **удодовые**

**ҺӨҖҮ** *и. гар. иск.* Сатира. *Халыкның һөҗү куәте дә җырларга тәэсир итми калмаган.* Гали Рәхим. *Кияү балакай Закир әфәнде хакында исә һәммә сүз һөҗү вә көлкедән гыйбарәт иде: кайсылары «башы күккә тиярлек», ди. Икенче берәүләре «буе манара кебек», ди.* Г.Ибраһимов

**ҺӨҖҮВИ** *с. гар. иск.* Сатирик. *Җырларыбыз арасында, сирәк кенә булса да, очраштыргалыйлар, һөҗүви җырларның мәүзуглары төрле-төрле була.* Гали Рәхим. *Поэманың сюжеты – һөҗүви әйбер.* М.Җәлил

**ҺӨҖҮМ** *и. гар.* 1) *хәрби* Дошманга таба юнәлгән, аны тар-мар итү, аның тере көчләрен юк итү, хәрби техникасын кулга төшерү һәм мөһим районнарны яулап алу максаты белән үткәрелә торган төп сугыш хәрәкәтләре. *Безнең фронтта һөҗүм сугышлары да шактый вакыт тынып торды.* Ә.Еники. *24 август иртәсендә дивизия Грачи совхозы, Котлубань станциясе һәм авылы юнәлешендә һәм аннары Малая Россошкага таба киң фронтта һөҗүмгә күчте.* Казан утлары

2) Гаскәрләрнең зур тизлек белән дошман, аның ныгытмалары һ.б.ш. өстенә ябырылуы, ташлануы; атака. *Ул көнне дошман бик көчле һөҗүм башлады.* А.Мансуров. *Һөҗүм ысулы да бик дөрес сайланган иде: башта дошман өстенә иң әзерлекле, иң каһарман яугирләр чирүе ташлана.* М.Әмирханов

3) Гомумән кемнең дә булса зур тизлек белән кемгәдер ташлануы. *XIV гасырның 60 нчы елларында мөстәкыйльлеккә ирешкән Алтын Урда бәкләре Булат Тимер һәм Тагай тиздән Болгар һәм Наручаттан күршеләренә һөҗүм ясый башлыйлар.* Б.Хәмидуллин

4) Кемгә яки нәрсәгә дә булса дошманлык нияте белән ташлану; гомумән кемгә дә булса каршы хәрәкәт итә башлау. *Карагруһчылар һөҗүме башлангач, [Хәләф Гарданов] халыкара хокук оешмаларына барып керде, Гаага судына ук мөрәҗәгать итте.* Г.Гомәр. *Явыз кортлар һөҗүме аша үтеп, каравылчы йортына килә Килмешәк.* К.Җәмит. *Организмга чит-ят, зарарлы җисемнәр күбрәк кергән саен, аларга ак күзәнәкләрнең һөҗүме, ябырылуы да көчәя төшә.* Ф.Бәйрәмова

5) Зыян салу өчен, бик күп булып берьюлы ябырылу. *Черки яуларының һөҗүмен искә алмаганда, төн тыныч үтте диярлек.* Я.Зәнкиев. *Әле кичә генә телевизордан Африка илләренә саранча һөҗүмен күрсәттеләр.* Р.Мөхәммәдиев

6) Кемнең дә булса тормышына, иминлегенә зур куркыныч тудыру, талау, үтерү максаты белән ташлану. *1887 елның 1 мартында, патшага һөҗүм оештыручыларның берсе буларак, Александр Ульянов та кулга алына.* А.Тимергалин. *Татарстандагы эре банкка, Интернет аша ясалган һөҗүм нәтиҗәсендә, 300 миллион сумлык зыян килә.* Әлмәт таңнары

7) *спорт* Командалы спорт уеннарында яки шахматта зур осталык белән алга үтеп, ыргылып, каршы якны кысрыклау хәрәкәте. *Мастер барлык утыз тактада да аклар белән генә уйнады. Беренче булып һөҗүмгә күчү мөмкинлеге аның кулында.* А.Хәсәнов. *Икенче периодта Новосибирск кунаклары, көчле һөҗүмнәр ясап, исәпне ике шайбага кыскарттылар.* Туган як

8) *спорт* Команданың тупны, алканы көндәшләрнең капкасына (кәрзиненә) кертү бурычы торган өлеше; һөҗүмчеләр. --- *беренче ук булмаса да, дөньяның иң яхшы һөҗүм уенчыларыннан санала.* Ватаным Татарстан

9) *күч.* Тиешле максатка ирешү өчен, кемгә яки нәрсәгә каршы актив эш, хәрәкәт, көрәш. *Большевиклар хакимияте ныгып урнашып, дингә каршы һөҗүм башлаган дәһрилек чорында була әлеге хәл.* Ф.Зариф

10) *күч.* Кискен рәвештә риза булмыйча, кемгә яки нәрсәгә дә булса каршы чыгыш. *Тәнкыйтьчеләренә каршы һөҗүм*

11) *күч.* Нәрсәгә дә булса интенсив, кискен рәвештә начар тәэсир ясау (табигать көчләре тур.). *Кар суларының һөҗүме вакытын якынча белеп була, ичмасам, ә ярсуның ташып чыгар вакытын --- берничек тә чамалап булмый шул.* Шәһри Казан // Кинәт, интенсив рәвештә зыян салып килү, тоту, биләү. *Бу – инсульт һөҗүме... Була торган хәл... Даруларыгызны эчегез дә ятыгыз...* Д.Гыйсметдин

12) *күч.* Уй, фикер, хисләрнең кинәт биләп алуы. *– Рәхмәтеңә рәхмәт,*

*сеңелкәем, – диде Толымбикә, хис һөҗүменнән арынып.* М.Әмирханов

13) *күч. кит.* Көчле тәнкыйть. *Быелгы язгы каникулда укытучылар аңардан, нигә сез язган дәреслекләргә әледән-әле һөҗүм ясап торалар, ә сез берсенә дә җавап бирмисез, дип сораганнар икән.* А.Әхмәдуллин

**ҺӨҖҮ́М ИТҮ** *ф.* 1) Актив сугыш хәрәкәтләре белән алга, дошманга таба бару, дошманны кысрыклау. *Болгар илен сытып узар өчен, Кемнәр генә һөҗүм итмәгән?!* Х.Җәгъфәр. *Армия киң фронт белән һөҗүм итә*

2) Зур тизлек белән дошман, аның ныгытмалары һ.б. өстенә ябырылу, ташлану; атакага бару. *Әгәр синең ханың көтмәгәндә һөҗүм итмәгән булса, җиңүнең кем ягында буласын күргән булыр идегез.* Э.Яһудин

3) Кемгә яки нәрсәгә дә булса дошманлык нияте белән ташлану; гомумән кемгә дә булса каршы хәрәкәт итә башлау. *Әмирҗаннар бандасы коммунага һөҗүм итәргә әзерләнә.* Ш.Камал

4) Зыян салу өчен, бик күп булып берьюлы ябырылу. *Бервакыт, Тәкәнештән төнлә туган авылына кайтканда, басуда аңа [Нухка] бүреләр һөҗүм итә.* Ш.Мостафин

5) Кемнең дә булса тормышына, иминлегенә зур куркыныч тудыру, талау, үтерү максаты белән ташлану. *Патшага һөҗүм итү*

6) *спорт* Командалы спорт уеннарында яки шахматта зур осталык белән алга үтеп, ыргылып, каршы якны кысрыклау. *55 нче минутта Казан командасы ветераны Олег Петров, шайбасыз уенчыга һөҗүм итеп, «Ак Барс»ны уңайсыз хәлгә калдырды.* Шәһри Казан. *Үзәктән һөҗүм итү*

7) *күч.* Тиешле максатка ирешү өчен, кемгә яки нәрсәгә каршы актив хәрәкәт, көрәш башлау. *Күкләрне күкрәтеп, Җирләрне тетрәтеп Һөҗүм итте эшче дөньясы.* Г.Камал. *Башкача уйлаучыларга һөҗүм итү*

8) *күч.* Кискен рәвештә риза булмыйча, кемгә яки нәрсәгә дә булса каршы чыгыш ясау. *Дустлар, тугры юлдан китик, Ишаннарга һөҗүм итик; Тозакларын вәйран итик: Тагы бер кәррә кормасын!* Г.Тукай. *Әгәр бәйләнә башласалар, Гөлшәһидә акланып утырмаска, ә һөҗүм итәргә булды.* Г.Әпсәләмов

9) *күч.* Нәрсәгә дә булса интенсив, кискен рәвештә начар тәэсир ясау (табигать көчләре тур.). *Бу дулкыннар кубарса да шау-шу, гауга, Һөҗүм итеп килсәләр дә, охшап яуга, – Шунда үсеп тора торган олуг таш-тау зәррә хәтле зарарланмыйча калды сау.* Г.Тукай. *Диңгез коры җиргә һөҗүм итә* // Кинәт, интенсив рәвештә зыян салып килү, тоту, биләү. *Аерылышуларның күбәюе, балаларга карата каты күңеллелек, рәхимсезлек – болар барысы да гаилә институтына һөҗүм итә торган күренешләр.* Г.Буби. *Глобальләштерү шаукымы (империализмның яңа шәкеле) милли көйләребезгә дә һөҗүм итә башлады, дөньякүләм бертөрле көйсезлек-моңсызлыкка тартып кертмәкче булалар.* Б.Рәхимова

10) *күч.* Уй, фикер, хис, халәт һ.б.ш. кинәт биләп алу. *Бәхетсезлек алар гаиләсенә иң нечкә җирдән – балалар аша һөҗүм итте.* Ф.Бәйрәмова. *Керфекләрен тырышып-тырышып ачарга теләсә дә, һәр тарафтан һөҗүм иткән караңгылык нәрсәдер пышылдаган ирләрнең да йөзен үзенә йомып алды...* Х.Ширмән

**ҺӨҖҮ́М КЫЛУ** *ф. иск. к.* **һөҗүм итү**. *24 нче числога каршы төндә сыйнфый дошманнар колхоз яшьләре мәктәбе мөдирәсе Разия Баязитовага һөҗүм кылдылар.* А.Алиш

**ҺӨҖҮМЛЕ** *с.* Һөҗүм тактикасы белән алып барылган; һөҗүмчән. *Кайбер халыкларның Каспий буе, Кара диңгез аша Закавказье, Иран, Кече Азия тарафына шундый ук һөҗүмле агымын Төньяк (мех) сәүдә юлы кузгаткан хәрәкәт дип билгели алабыз.* М.Гайнетдин. *Команданың яңа уен стилен эзләвен, һөҗүмле футболны сайлавын беләбез.* Ватаным Татарстан

**ҺӨҖҮМЧӘН** *с.* 1) *к.* **һөҗүмле**. *Күренә ки, яңа чор бусагасына килгәндә, бу халык традицияләрендә һәм стратегиясендә яңа заман сораган форматтагы һөҗүмчән, сугышчан оешканлыклар булмаган.* М.Гайнетдин

2) Һөҗүм итеп тора торган, шуңа сәләтле. *Канда менә шушы һөҗүмчән һәм саклагыч күзәнәкләр ясалу үзләре бер система тәшкил итәләр.* Ф.Бәйрәмова

3) *күч.* Агрессив, басып алуга, басым ясауга нигезләнгән. *Минемчә, иптәшләр, бөтен сәбәп – эчүчелеккә каршы һөҗүмчән көрәш алып бармауда.* Ф.Садриев. *Шуңа күрә дә революциянең һөҗүмчән рухын раслаучы, алдынгы көчләргә дан җырлаучы, яңа тормышны пропагандалаучы әсәрләргә киң урын бирелә.* М.Мөхәррәмов, А.Әхмәдуллин

4) *күч.* Үткен, аяусыз, кызганусыз. *Шуңа күрә «канга – кан, үлемгә – үлем!» дигән сүз шигарь генә түгел, халык күңеленә иңдерелгән һөҗүмчән максат та иде.* Р.Фәйзуллин. *Лаборатория мөдиренең көймәсен комга терәргә теләп, ул бер-бер артлы һөҗүмчән сораулар яудыра башлады.* З.Мәхмүди

**ҺӨҖҮМЧӘНЛЕК** *и.* Һөҗүмчән булу. *Катлаулы чор иде – сталинизм шаукымы астында әдәбиятка һөҗүмчәнлек, кан коярга чакыру тенденциясе дә килеп керде, журналда болары да басылды.* М.Мәһдиев

**ҺӨҖҮМЧЕ** *и.* **1.** *спорт* Кайбер командалы спорт уеннарында һөҗүм итүчеләрнең берсе; форвард. *Итекләре авыр дип тормады Равил, үзәк һөҗүмче булып уйнады.* В.Нуруллин. *29 яшьлек һөҗүмче моңа кадәр Кытайдагы «Ценг Тоу» клубы данын яклады.* Ватаным Татарстан

**2.** *с. мәгъ.* Һөҗүм иткән, һөҗүмдә катнашкан. *Аларның җайдаклары һөҗүмче якны ә дигәнче камалышка алды.* В.Имамов. *Һөҗүмче кемсә аны (Сөембикәне) ятагында ук юрганына төреп бәйләде дә иңенә күтәрде.* М.Әмирханов

**ҺӨНӘР** *и. фар.* 1) Нинди дә булса эшчәнлек белән бәйле белгечлек, профессия; квалификация. *Шофёр идем мин... Яхшы һөнәр!* А.Гыйләҗев. *Металлург эше – «кайнар һөнәр», Салкын акыл кирәк, корыч кул.* Г.Сафин

2) Нәрсә дә булса ясау, җитештерү өчен махсус күнекмә таләп итә торган эш, кәсеп, шөгыль. *Казанда шактый халыкның һөнәр-сәүдә белән шөгыльләнүе Казанның ханлыкта зур сәүдә үзәге булуын күрсәтә...* Б.Хәмидуллин. *Бу сәләтле бала тугыз яшьтән үк тегү һөнәренә өйрәнә.* З.Мәхмүди

3) Үзенә хас алым һәм методлар системасы булган берәр төрле практик эш, эшчәнлек. *Ниһаять, яшь мәгърифәтче шул заман шартларында үзе өчен иң кулай булган һөнәр – китап бастыру һәм тарату эше белән шөгыльләнергә әтисенең ризалыгын ала.* Г.Камал. *Бу дөньяда гүя кер элүдән рәхәтрәк башка һөнәр юк.* Г.Гыйльманов

4) Нәрсәгәдер зур осталык, маһирлык, эшне белү. *Балалар өчен тапшыруларда алып баручылар, «маладис» дип, һөнәр күрсәткән баланың башын-

*нан сыйпый.* Р.Батулла. *Мич чыгарганга Пачарлардан да тиясе әле, пима да төпли башлады – кулы һөнәр белә, Аллага шөкер.* З.Зәйнуллин

**ҺӨНӘРДӘШ** *и.* Бер үк төрле һөнәр белән шөгыльләнүче кешеләрнең һәрберсе. *Шуңа күрә аны, һөнәрдәшләреннән аерып күрсәтү өчен булса кирәк, остаз дип йөртә башладылар.* С.Поварисов

**ҺӨНӘРИ** *с. фар.* Нинди дә булса һөнәр белән бәйле, шуңа караган. *Аларны һөнәри бәйрәмнәре белән котлыйк.* Н.Галиев. *Менә шушы укытучының һөнәри категориясен күтәрү өчен тест үтеп кайтып килеше иде.* С.Зыялы // Гомумән һөнәрләргә, профессиональ эшчәнлеккә караган. *Магистратурада ике ел укыганнан соң, алар магистр дәрәҗәсендәге югары һөнәри белем турында диплом алачак.* С.Нәҗмиев

**ҺӨНӘРЛЕ** *с.* **1.** 1) Нинди дә булса һөнәре, профессиясе, белгечлеге булган. *Сугыш башлангач, цехта һөнәрле эшчеләр бик нык кимеде.* Г.Әпсәләмов

2) Кулы эш белгән, булдыклы, берәр осталыкка ия булган. *Җире рәтсез якта халык һөнәрле була.* М.Мәһдиев. *Ян тәрәзә янындагы кечкенә тәбәнәк өстәл өстенең эш кораллары белән тулганлыгы хуҗаның һөнәрле кеше булуы хакында сөйли.* Р.Рахман

3) Өйрәтелгән (хайваннар тур.). *Мин ишеттем, сезнең һөнәрле карчыгаңыз бар, имеш.* К.Насыйри

**2.** *и. мәгъ.* Һөнәре булган кеше, оста. *Һөнәрле үлмәс, һөнәрсез көн күрмәс.* Мәкаль

**ҺӨНӘРЛЕЛЕК** *и.* Һөнәрле булу. *Әйе, күп һөнәрлелек синең әдәби эшчәнлегеңдә дә чагыла.* Р.Вәлиев

**ҺӨНӘРМӘНД** *и. фар. иск.* Алтын куллы кеше; күп һөнәргә ия булган кеше. *Ул вакыт һөнәрсезнең ярамас эшен күреп, аның яхшысын эшләмәгә иҗтиһад кыл, һөнәрмәнд булырсың.* К.Насыйри. *Ихатада сарык кабыргасы сөяге табылгач, ул инде үзен иң оста шымчыларның да остасы икәнлеген раслый белүче һөнәрмәнд дип уйлады.* С.Поварисов

**ҺӨНӘРСЕЗ** *с.* **1.** 1) Нинди дә булса һөнәре, профессиясе, белгечлеге булмаган. *Кул буеның мәдрәсә талибләре Барча байлыкны җыячаклар, имеш, Һич һөнәрсез бай булачаклар, имеш.* Г.Тукай

2) Нинди дә булса осталыкка ия булмаган, булдыксыз, кулы эш белмәгән. *Күбрәк һөнәрсез атадан һөнәрсез бала туа, димәктер.* К.Насыйри

3) Эш рәте белмәгән, бер эшкә, тәртипкә өйрәтелмәгән. *Падишаһ, гаять гайрәтләнеп: – Бар, кит, һи, һөнәрсез ахмак! --- – диде.* К.Насыйри. *Мәрфуга апа мине, бигрәк һөнәрсез малай бит бу, дип уйлый торгандыр...* Ф.Әмирхан. *Әлегә һөнәрсез малайда башкаларның гаме дә юк шул.* Р.Рахман

**2.** *рәв. мәгъ.* Һөнәре булмаган хәлдә, һөнәре булмыйча торып. *Бервакытны болар [болгарлар] һөнәрсез, гыйлемсез, дәүләтсез булып калып, кара хезмәтләрдә генә гомерләрен үткәрмешләрдер.* Г.Исхакый. *Һөнәрсез эшләп булмый*

**3.** *и. мәгъ.* Һөнәре булмаган кеше. *Һөнәрсез сине күрә алмас, Илдән илгә җилеп үтсәң дә, Бу дөньялар сиңа да калмас!* Дастан

**ҺӨНӘРСЕЗЛЕК** *и.* 1) Һөнәрсез булу. *Ул елларда көтүчелек иң түбән һөнәр исәпләнә иде. Хәтта һөнәр дә түгел, һөнәрсезлек санала, ягъни кулыннан башка бернинди дә эш килмәгән кеше генә көтүче була, дип карыйлар иде.* М.Әмир

2) Ялкаулык, эшлексезлек, булдыксызлык, эшкә өйрәнү теләге булмау. *Табигате һөнәрсезлек тарафына юнәлсә, ул баланы тәртипкә салмак читендер.* К.Насыйри. *Эш кешене төзәтә, эшлексезлек, һөнәрсезлек белән кеше булып булмый.* Р.Зарипов

**ҺӨНӘРХАНӘ** *и.* Һөнәрче алачыгы, остаханә, кярханә. *Халык арасында Алтын кыр дип аталган бу җирдә Күчем ханның яшерен корал һөнәрханәләре урнашкан --- иде.* Ф.Бәйрәмова. *XIV гасыр катламында җиде корылма табыла, шуларның дүртесе – һөнәр алачыклары (ике чүлмәк ясау һөнәрханәсе, --- йозакчы һәм күн эшкәртүченең торагы һәм һөнәрханәсе).* Б.Хәмидуллин

**ҺӨНӘРЧӘН** *с. к.* **һөнәрчел 2.** *Азгын бай булудан саф вә һөнәрчән фәкыйрь булуны артык күрегез.* Р.Фәхретдин. *[Әҗем] Казан малтабарларына, һөнәрчән ил агаларына: – Ерактагы туганымның углының углы, зәргәр Галиәкбәрнең кияве сәүдә эшендә үзенә юл сапмакчы, – дип таныштырды.* Ф.Латыйфи

**ҺӨНӘРЧЕ** *и.* Берәр һөнәргә (*2 мәгъ.*) ия булган һәм гади җитештерү кораллары белән нинди дә булса эшләнмәләр ясап сатучы кеше. *Биләмә кенәзләре арасындагы туктаусыз кан коюдан игенчеләр, һөнәрчеләр күптән гарык булган.* В.Имамов. *Кальганың үзен һөнәрчеләр, кече кешеләр бистәләре уратып алган.* И.Хуҗин

**ҺӨНӘРЧЕЛ** *с.* 1) *ялг.* Һөнәр яки һөнәрчелек белән бәйле; һөнәргә нигезләнгән. *Көнчыгыш белән культура һәм экономика өлкәсендә бәйләнешләр көчәя, һөнәрчел җитештерү киңәя.* Казан утлары

2) Төрле һөнәрләргә оста, маһир. *Ә Габдулла Кариев мәдрәсәдә укыган чакта аның [Тукайның] «һөнәрчел» булуы, хәтта рус шигырьләрен дә көйләп йөрүе турында искә ала.* З.Мансуров

**ҺӨНӘРЧЕЛЕК** *и.* Һөнәрче эше, шөгыле; һөнәрче булу. *Казан һәм башка ваграк шәһәрләр урыс хәрби кирмәннәре буларак элеккедән дә артык ныгытылсалар да, һөнәрчелек һәм сәүдә үзәге буларак яшәүдән туктыйлар.* З.Мифтахов

**ҺӨНӘРЧЕЛЕ́К ИТҮ** *ф.* Һөнәрчелек белән шөгыльләнү, һөнәрче булу. *Яшь баласын тартып кыр түренә Таңнан эшкә киткән әнием. Ат дагалап, чалгы, төрән таптап, һөнәрчелек иткән әтием.* Э.Мөэминова

**ҺӨҢГЕ́Р-ҺӨҢГЕР** *рәв.* Үксепүксеп, шыңшый-шыңшый. *Ни каты бәгырьле кешене дә һөңгер-һөңгер елата торган әхлаксызлыкларга да күнегеп килә «болгарлар»ың, Җәгъфәр әфәнде!* А.Тимергалин

**ҺУ** I *ы.* 1) Шатлану, соклану, горурлану хисләрен белдерү өчен кулланыла. *– Һу-у, күршеләр килгән икән, түрдән рәхим итегез, – дип, ярты пот бодайны кадерләп кенә кулына алды.* М.Мәһдиев. *Һу-у, кылыч уенын көтеп ала иде Үтәмеш хан.* Р.Батулла

2) Гаҗәпләнү, аптырау, курку яки ризасызлык хисләрен белдерү өчен кулланыла. *[Сәркатип:] Утызлап гариза бар. [Әгъза:] Һу, бигрәк күп икән.* Г.Камал

**ҺУ** II *иярт.* Ерактан кычкырып эндәшү яки җавап бирү тавышын белдерә. *Урман «һу» дип сузып җавап бирде.* Г.Исхакый

**ҺУН** *и.* IV гасырда Көнчыгыш Уралда Үзәк Азиядән чыккан хуннар (сөннәр) белән җирле сармат һәм угор кабиләләре катнашында оешкан кабиләләр берләшмәсе вәкиле; *русчасы:* **гунн**. *Аттиланың вакытсыз вафаты һуннар арасында эчке бәрелешләргә китерә.* Т.Кәримов. *Әмма шуның белән бергә һуннарның монгол булмавы да күптән ачыкланган факт бит.* Ф.Урманче

**ҺУП** *ы. к.* **һоп**. *Мәймүн, һуп-һуп сикереп, төрле тавышлар белән кычкырыр иде.* К.Насыйри. *Җыен иске, җыен чүп Сикерешәләр һуп та һуп!* Г.Камал

**ҺУШ** *и. фар.* 1) Аң, ис; зиһен. *Ни хакың бар синең моны һуш җуярлык дәрәҗәдә авыр кабул итәргә.* Ә.Баян. *Ул көнне Хәмит көн уртасына кадәр һушында иде, кулын Гөлчирәгә сузды да хырылдый башлады һәм тынсыз калды.* Д.Каюмова

2) Сәламәт акыл, уйлау сәләте; гакыл. *Бүген миңа йөрәк әйтте: Барып кил аңа, диде. Аның да һушы сәламәт, Йөрәге яна, диде.* А.Хәлим. *Килеп дөрес эшләгәнсең, Сәет. Тик... минем көчем җитәр микән соң? Һушым җитәр микән?* Г.Гыйльманов

◊ **һуш аву** *к.* **һуш китү**. *Тышкы ялтыравыгына исем китеп, һушым авып йөргәнмен икән. Эче тулы агу икән ул чибәркәйнең.* А.Гыйләҗев. **Һуш башка килү** *к.* **һушка килү** (*1 мәгъ.*). *Аракы эчтем – хушландым. Һушым китеп, буш калдым; Һушым башка килгәнче, Эш урынымнан буш калдым.* Н.Исәнбәт. **һуш җыю** Хәл алу, берәр төрле киеренке хәлдән соң тынычлану, зиһен җыю. *Хәлим, агач астында калмас өчен, читкә тайпылырга кирәген белә, әмма, һушын җыеп, гәүдәсен һәлакәт астыннан ала алмый иза чигә иде.* Г.Гыйльманов. *Сәкинә бирмәл, фикерләү сәләтен югалтып, һушын җыялмыйча торды.* Г.Әдһәмова. *Күзләреннән очкыннар чәчелде Шәүкәтнең, бертын һушын җыя алмый ятты.* К.Кара. **Һушка килү** 1) Аңга килү, үз-үзеңне һәм тирә-якны сизү, аңлау хәленә кайту. *Пётр озын гына һушсыз ятканнан соңында һушка килә.* Г.Исхакый. *Һушка килеп, сикереп торган идем, кая ул, тегеләрдән җилләр искән.* Ф.Сафин; 2) *к.* **һуш җыю**. *Мунчадан соң әле озак кына һушка килә алмый йөрисең.* Р.Зәкуан; 3) Берәр төрле башкарылган эшнең яки ниятнең ялгышлыгын аңлап, аннан кире кайту, аны төзәтергә омтылу. *Бохари муллалар, һушларына килгәч, болай очып йөрүнең шәригать буенча дөресме, түгелмелеген [тикшерергә] керештеләр.* Ф.Әмирхан. **Һуш керү** *к.* **һушка килү** (*1 мәгъ.*). *Күпме вакыт узгач һуш кергәндер – анысы билгесез, әмма теге «полковник ханым» «операциясен» уңышлы үткәргән, диделәр.* Л.Әблиева. **Һуш китү** 1) Аңны югалту. Бәс, безнең милләт үлмәгән дә, йокламаган да, һушы гына киткән. Г.Тукай. *Күп кенә тол хатыннар ачтан, талчыгудан һушы китеп егыла, әмма авызына бер уч бодай каба алмый.* Я.Шәфыйков. *Бернинди хәл юк, вакыты белән һуш китеп ала.* Ә.Моталлапов; 2) Нәрсә дә булса уйларлык, эшләрлек хәлдә булмау, аңгы-миңге хәлдә булу; зиһен чуалу. *Ләкин бу гаҗәп вакыйга сәбәбеннән беркадәр һушым китте дә сөйләшә алмый тордым.* Р.Фәхретдин. *Мирзахан көтелмәгән бу ударлан һушы китеп, лып итеп диванга утырды.* Р.Батулла; 3) Акылдан язу, шашу, тилерү. *Кайчан бер аять иңдерелеп сугыш зекер ителсә, күңелләрендә Аллаһуга каршы чир булган монафикъларны күрерсең, алар, үлемнән куркып, һушы киткән кешенең каравы кеби сиңа карарлар, чөнки алар яратмаган үлем сугышта аларга якын киләдер.* Ногмани; 4) Бик нык соклану, кызыгу, ис китү, мөкиббән китү; гаҗәпләнү, шаккату. *Шулай да Фәләхнең әнисе койган казылыкка һушы киткән әнә [министрның]...* В.Нуруллин. *Тик минекеләрнең велосипедка һушлары китми, алар, нишләптер, машинада утырып йөрергә ярата.* Ф.Төхбәтуллин. *Шушы вакыйга исемә төшә дә, гаҗәпләнүемнән һушларым китә: миллионнарча кешеләрне ничек итеп шушы кадәр үк ышандыра алдылар икән?* Я.Шәфыйков. **Һушны алу** 1) Акылдан язар дәрәҗәдә куркыту. *Икенче көнне, иртәнге сәгатьтә үк, сәламәтлек саклау бүлегеннән Галиев шалтыратып, Кадриянең һушын алды: – Монда, башкарма комитет каршына, Татар иҗтимагый үзәге вәкилләре җыелып килгән.* В.Имамов; 2) Аңгымиңге хәлгә китерү, зиһенне чуалту. *Фикеренең җебе, сүзенең рәте-бите юк. Очрашу сөенеченнән шулай каушап калдымы, әллә, чыннан да, дөмбәсләп һушын алганнармы бичараның?* Т.Галиуллин; 3) Сокландыру, кызыктыру; гаҗәпләндерү, шаккатыру, ис-акылсыз калдыру. *Гомерендә күрмәгән затлы киемнәр һушын алды Гөлбануның.* Т.Гарипова. *Алар бер-берсенә нәзакәтле мөнәсәбәтләре белән кодаларының һушын алырга ярата.* Ф.Садриев. *Әмма егет тә кеше иде яшь чагында бабаң! Бөеренә таянып, бер җырлап җибәрсә, кунакларның һушын ала иде.* Ә.Еники; 4) Гашыйк итү. *Дамирына чыкканчы, никадәр егетнең һушын алды бу күзләр.* Ф.Яруллин. *Ничәмә кызның һушын алган егет.* Ф.Яхин. **Һушны җибәрү** *к.* **һушны алу**. *Инфир – авылда шофёр. Үзен хатын-кызның һушын җибәрүче дип саный.* Р.Сәгъди. *Йорт хуҗасы төнге бакчаның теләсә кемнең һушын җибәрерлек эффект ясаганын үтә яхшы белә иде.* Р.Мирхәйдәров. **Һуштан аву** *к.* **һуштан язу**. *Зәңгәр олы күзләрең бер сирпесәң, Бетте инде – бөтен кеше һуштан ава.* Ш.Бабич. *Һуштан ауганчы безләр сыктадык, Кайгы-сагыштан бергәләп сыкрандык.* Ф.Бәйрәмова. **Һуштан китү** 1) *к.* **һуштан язу**. *Буш күзләргә карап тора шагыйрь, һуштан китеп тора: «Мин кайда?!»* К.Сибгатуллин; 2) Акылдан язу, шашу, тилерү. *Тегендә ана һуштан китте, булды дивана; Бердәнбер углын югалту нинди авыр хәсрәт аңа.* Г.Камал. **Һуштан таю** *к.* **һуштан язу**. *Кара теге чибәр кызны! Һушыннан тайган булып ята.* Г.Камал. **Һуштан яздыру** *к.* **һушны алу**. *Кыз-хатынны егет-ирләрнең холкы да, йөз-кыяфәте дә түгел, тасма теле һуштан яздыра.* З.Хөснияр. **Һуштан язу** 1) Аңны югалту. *Районга алып баргач, таныш врач: – Абзый, аягың сынган, гипс салабыз, – дигәч, Сабирулла һушыннан язды.* И.Хәйруллин; 2) Хәйран булып сокланудан ис китү, таң калу. *Әмма егет һушыннан язмады, дөресрәге, һичнәрсәне, һичкемне сизмәс булса да, җырны ишетүдән туктамады.* Ә.Еники

**ҺУШ-АКЫЛ** *җый. и. к.* **ис-акыл**. *Берсе – күренеп торган инвалид, тумыштан аяклары йөрми, икенчесенең һуш-акылы дөрес түгел.* Кәеф ничек?

◊ **һуш-акыл китү** *к.* **ис-акыл китү**. *Керсәм, Гөлкәйгенәй, һушым-акылым китә язды: әйтерсең кабыгы суелган калын бүрәнә, Лотфыйның уң аягы менә шулай булып шешеп ята.* Г.Ибраһимов. *Хезмәт хаклары уртача Кырык биш меңгә җитә. Ул «меңнең» тиеннәрен чутлап Һушым-акылым китә.* Ф.Вәлиев

**ҺУ́ШКИТӘРЛЕК** *с. к.* **искитәрлек**. *Башым иеп чыгып киләм менә [татар баеның] Һушкитәрлек затлы йортыннан.* Ф.Җамалетдинова

**ҺУ́ШКИТМӘЛЕ** *с. к.* **искитәрлек**. *Шундый һушкитмәле кызның Наилләр классына туры килүе – үзе зур горурлык.* К.Кәримов

**ҺУШЛАНУ** *ф.* Акыл керү, аң дәрәҗәсе үсү. *Бала үсәр, тиле һушланмас.* Мәкаль

**ҺУШЛЫ** *с.* Акыллы, зирәк, зиһенле. *Кытайлар да баскыннарны Дивар яктан көткәннәр. Ә тегеләр һушлы булган: Читтән урап киткәннәр.* И.Гыйләҗев. *Мәдехия тутигә егет буйлы-сынлы булуы белән генә түгел, үзен ипле тотуы, олыны олы итеп, җайлы сөйләшә белүе, камил акыллы, һушлы булуы белән дә ошады.* Р.Кәрами

**ҺУШСЫЗ** *С.* **1.** Аңсыз, һушын җуйган, биһуш. *Ярый әле шундук һушсыз хәлдә самолётта Владивостокка озаттылар.* С.Сабиров. *Инде сынган, өзелгән дип исәпләнелгән хисләренең нәзек кыллары тибрәлеп куюдан бичара Фәхри Хисами ничек тә мәрхәмәтсез, ышанычсыз дөньяга кайтырга теләгән һушсыз адәм халәтеннән чыгарга омтылыш ясады.* Ф.Яхин

**2.** *рәв. мәгъ.* Аңсыз хәлдә, һушын җуеп, биһуш булып. *Монысы күршеләрнең тәмлетамак ата песие – Наполеон. Мин ике адым ясаганчы, ул койма башыннан гына кар өстендә һушсыз яткан карчыга өстенә сикерде.* А.Хәсәнов

◊ **һушсыз итү** Таң калдыру, хәйран калдыру, гаҗәпләндерү. *Менә шул Әнәс Рухиягә аеруча хөсетләнә: юл өстендә туры килмәсә дә, үзе эзләп табып, аның Равилне һушсыз иткән озын толымнарыннан тартып китә.* В.Нуруллин. *Нәкъ шул көннәрдә Сабирҗанга, солдатка каралырга дип, печатьле кәгазь тоттырдылар. Бу хәл Сабирҗанны һушсыз итте.* М.Хәсәнов. **һушсыз калу** 1) *к.* **һуштан язу**. *Вәлиәхмәтов тагын һушсыз калды. Аңына килә алмый ике көн саташып яткан, дип сөйләделәр.* Р.Максудов. *Бер яктан, күңелне әнә шул уй борчый, икенче яктан, Хафиз картның кружкалап хәмер эчүенә һушсыз калган идем.* В.Нуруллин. *Мин кечкенә инештән бәреп торган тузганак-фонтаннарга сокланып һушсыз калдым.* Г.Әдһәмова

**ҺУШСЫЗЛАНУ** *ф.* 1) Аңны югалту, һуштан язу. *Ягъкубның моны ишеткәч акылы шашты, Бер кычкырып, һушсызланып, авып төште. Моны күреп, угланнары кайгырышты: «Аһ, үкенеч, хата кылдык!» – диләр имди.* Кол Гали

2) *куч.* Югалып калу, нишләргә белмичә тору // Ваемсызлык, гамьсезлек күрсәтү

**һушсызланып тору** Вакытлыча һушсызлану. *[Зимин (беркавым һушсызланып торганнан соң кобурасыннан пистолетын чыгара):] Атам!* З.Хәким

**һушсызланып утыру** *сөйл. к.* **һушсызланып тору**. *[Нурдидә:] --- Ярый, вакытым кысан. Һушсызланып утырма, акчаңны яшереп куй.* З.Хәким

**ҺУШСЫЗЛЫК** *и.* Һушсыз, аңсыз булу хәле. *Төпсез упкынга төшеп киткәндәй, һушсызлык караңгылыгына чумган Семичастный үзе дә «Юлда үләр... Илтеп җиткерә алмаслар» дигән сүзләрне ишетеп ятты.* Г.Әпсәләмов

**ҺЫ** *ы.* Аптырау, гаҗәпләнү, канәгатьсезлек хисләрен белдерү өчен кулланыла; һе. *Һы, тапкан кызык. Биеп тә, акробат дигәнеңчә кыланып та көн күрә кайбер адәмнәр.* Ә.Баян. *– Һы! – дип куйды сержант. – Биш көн нарядка да түзмәгәч! Боламык!* З.Хөснияр

**ҺЫК** *иярт.* Сулыш кысылып тын өзелгәндә, очкылык тотканда һ.б.ш. очракта барлыкка килгән өзек бугаз тавышын белдерә. *Бичара агай һык итеп китте дә хәлсезләнеп җиргә чүкте.* В.Нуруллин. *Көтмәгәндә малай һык итте, гәүдәсе буйлап калтырану йөгерде, һәм ул күзләрен ачты.* З.Мурсиев

**ҺЫМ** *ы. к.* **һем**. *– Һым-м-м, – ди хәзрәт, авыр сулап. Һәм урта рәттәге мөсафиргә эндәшә: – Син, кем... Ишәгем югалды, дип зарланасың. Әнә ул – алып чык...* М.Мәһдиев. *Закиров күтәреп кенә: – Һым, чама белән... егерме ике-егерме өчне бирергә мөмкин, – диде.* Р.Кәрами

# Ц

**ЦА́НГА** *и. нем. тех.* Металл кисү станокларында эшкәрткәндә цилиндр яки призма формасындагы материалларны яки коралларны кысып беркетә торган, буйга киселгән втулка кебек җайланма. *Цанга ярдәмендә беркетү*

**ЦА́ПФА** *и. нем. тех.* Валның яки күчәрнең подшипникка таяна торган өлеше. *Тәгәрмәч цапфасы*

**ЦАРИЗМ** *и. рус* 1917 елга кадәр Россиядә чикләнмәгән югары хакимият монарх кулында булган идарә итү формасы; патша режимы. *Татарларның царизмга каршы милли азатлык хәрәкәтләрен ул юрист трибунасыннан торып яклый.* М.Мәһдиев. *Хәзерге вакытта бу хата нигездә төзәтелгән булса да, атамаларда царизм дәвереннән үк калган бөек мәмләкәтчел һәм шовинистик исемнәр сакланып килә икән әле.* А.Тимергалин

**ЦЕ́ЗИЙ** *и. лат. Химик элемент (Cs), көмеш ак төстәге селтеле йомшак металл. Мәсәлән, плутонийның ярымтаркалу чоры дистә меңнәрчә елга сузыла, стронций, цезий һәм башкаларныкы исә – йөзләрчә елга.* Ф.Зариф

**ЦЕЗУ́РА** *и. лат.* 1) *әд.* Шигырь юлы эчендә шул шигырь үлчәме өчен мәҗбүри тынныш, пауза. *Моңа шигырьнең интонациясе, ритмик буыннар, цезура һәм рифмалар мөмкинлек бирә.* Х.Миңнегулов. *Ә менә Дәрдемәнд һәм С.Рәмиев иҗатларында ачык иҗекләре дә, цезуралары да һәм табигый басымнары да сакланган шигырьләр белән очрашабыз.* Ә.Закирҗанов

2) *муз.* Көйдәге пауза. *Музыкаль формалар эчендә һәртөрле кисәкләр арасындагы бүленешләр фраза дип атала, фразаның тәмамланган урынына цезура диләр.* Ә.Бакиров

**ЦЕЗУ́РАЛЫ** *с.* Цезуралары булган. *Ләкин шунысы характерлы: цезуралы шигырьгә күнеккән төрки шагыйрьләр иҗатына сүз атландыру алымы механик рәвештә генә күчеп утырмаган.* М.Бакиров

**ЦЕЗУ́РАСЫЗ** *с.* **1.** Цезуралары булмаган; цезуралар белән башкарылмаган. *Туктамыш хан аңа каршы килеп, (1 нче һәм 3 нче юллар) цезурасыз җиде дә җиде үлчәме белән кистереп (өч юл да рифмалашкан) җавап бирә, сөйләм темпының да арта баруы күзаллана.* Г.Нуриев

**2.** *рәв. мәгъ.* Цезура кулланмыйча; цезура булмаган хәлдә

**ЦЕЙТНОТ** *и. нем.* 1) *махс.* Уенның дәвамлылыгы билгеләнгән рәсми шахмат яки шашка ярышларында уенчының йөрешләрне уйлап бетерергә вакыты җитмәү хәле. *Болар, шахматчылар цейтнотка эләккәч ясаган йөрешләр кебек, бик тиз булды.* М.Хуҗин

2) *күч.* Вакытның бик аз булуы, вакыт җитмәү. *Яшәү кыска. Аҗагандай! Үтә гомер цейтнотта!* Н.Гамбәр. *Иртәнге якта аның өчен һәрвакыт цейтнот бит: һәр көнне 32 укытучының 3–4 се булмаганлыктан, өчәр параллельдән торган унсигез сыйныфның дәресләр тәртибен көйлисе була.* Н.Көбәш

**ЦЕЙХГА́УЗ** *и. нем. хәрби иск.* Корал, кием-салым, азык-төлек һәм һәртөрле кирәк-яракларны саклау өчен хәрби склад. *Командирларының рөхсәтеннән башка гына алар цейхгаузларны һәм корал складларын ачтылар, кораллandылар.* Я.Чанышев. *Корбан бәйрәменнән кайткач, Лотфулла ике көннән снарядлар саклый торган цейхгаузны сакларга каравылга китте. Цейхгауз җир астында 6–7 метр тирәнлектә.* З.Зәйнуллин

**ЦЕЛЛОФАН** *и. фр.-гр.* **1.** 1) Целлюлозадан җитештерелгән су үткәрми торган үтәкүренмәле плёнка. *Аның өстенә дипломатымнан алып метр ярым озынлыктагы целлофанны капладым, шуның белән минем ятагым әзер булды.* А.Тимергалин

2) Шундый плёнкадан ясалган пакет, капчык кебек әйбер. *Шунда башта чистарак саналган ике капчык, аның өстенә целлофан җәйделәр һәм Мөнирҗанны сак кына кертеп яткырдылар.* Н.Әхмәдиев. *Целлофанга төрелгән күгелҗем тәлгәшләр бик зәгыйфь булып, алардан сизелер-сизелмәс җир исе аңкый иде.* М.Маликова

**2.** *с. мәгъ.* Шул плёнкадан ясалган, шуннан эшләнгән. *Кайбер тәрәзәләр ябык, кайберләренә карындыкны хәтерләткән целлофан җәймәләр тарттырганнар, пәрдәләрнең дә ябылып бетмичә, ачыграк калганнары бар.* Р.Фәйзуллин. – *Менә бит, менә бит, син шуны күр әле, – дип, кесәсеннән целлофан капчык чыгарды.* А.Хәсәнов

**ЦЕЛЛУЛО́ИД** *и. лат.-гр.* **1.** Нитроцеллюлозадан ясалган тиз янып китүчән сыгылмалы матдә (элек галантерея әйберләре, уенчыклар һ.б.ны җитештерү өчен киң кулланылган). *Өстәл теннисы шары целлулоидтан яки пластиктан ясала*

**2.** *с. мәгъ.* Шул матдәдән ясалган. – *Дүрт-биш җирдән җавап килде, берсендә дә өмет юк, – дип, Каймакчи тирән сулады. Кара замш пальто өстеннән кигән соргылт партупеялары шыгырдады, целлулоид ак якасы имән муенына батып керде.* Х.Камалов. *Чыршыны целлулоид уенчыклар, марля һәм мамык белән дә бизәргә ярамый.* Яшел Үзән

**ЦЕЛЛЮЛО́ЗА** *и. фр.* **1.** 1) Үсемлек күзәнәкләренең тышчаларын тәшкил иткән матдә; клетчатка. *Бериш аскомицетлар хайван үләксәсеннән калган җирлектә үсә, икенчеләре целлюлозага бай үсемлек калдыкларын неорганик молекулаларга кадәр таркатуда катнаша.* Биология

2) Үзагач һәм кайбер үсемлекләрнең сабакларын химик юл белән эшкәртеп табыла һәм кәгазь, ясалма ефәк, шартлаткыч һ.б.ш.ны ясауга китә торган матдә. *Гәрчә ул заводта целлюлозадан дары ясасалар да, Мотаһир аңа бар белгәнен дә әйтмәде.* Р.Кәрами

**2.** *с. мәгъ.* Шул матдәдән ясалган. *Целлюлоза сүс. Целлюлоза бөке*

**ЦЕЛОСТАТ** *и. лат. астр.* Күк сферасының тәүлеклек әйләнүе нәтиҗәсендә күчеп йөргән күк җисемнәрен күзәтү өчен хезмәт итә торган, әйләнмәле яссы көзгесе булган әсбап. *Целостат төзелеше*

**ЦЕЛЬ** *и. рус хәрби* Атканда яки ыргытканда тидерергә тиешле булган әйбер, нокта; һәдәф. *Бу вакытта ул, снаряд тиеп ишелгән вал кырыенда пулемётчылар взводының командиры – яшь кенә лейтенант белән янәшә яткан килеш, пулемётчыларга яңа цельләр күр-*

*сәтә иде.* Г.Әпсәләмов. *Бер бомба да цельгә төшми калган.* Р.Сәйфетдинов

**ЦЕМЕНТ** *и. лат.* **1.** 1) Төзелештә су кушып измә ясау өчен кулланыла торган тиз катучан үзле масса яки порошоксыман минераль матдә. *Кем рөхсәте белән Гәрәйне цемент алырга җибәрдең?* А.Гыйләҗев. *Цементка тоз кушсаң, ул катмый, сыек килеш кала, кипкәч тә уалучан була икән.* И.Сиражи

2) Шундый порошоктан ясалып каткан масса. *Бетон җылы һәм кытыршы иде. Вак цемент кисәкләре юкарган учына кадалдылар.* С.Шәмси

3) *анат.* Тешнең тамырын һәм муентыгын каплап торган сөяк тукыма

4) *күч.* Кемне яки нәрсәне дә булса нык, какшамас итеп бәйли, берләштерә торган нәрсә. *Туганлык цементы*

**2.** *с. мәгъ.* Шундый минераль матдәдән ясалган. *Мескен Зигизмунд, әрнүгә түзә алмыйча, цемент идәндә тәгәрәптәгәрәп ауный башлады.* Г.Әпсәләмов. *Озынлыгы биш, киңлеге өч метр чамасындагы таш капчык – тәрәзәсез дүрт цемент стена.* И.Салахов

**ЦЕМЕНТА́ЦИЯ** *и. рус* 1) *тех.* Затлы булмаган металлардан кысрыклатып, эремәләрдән алтын, көмеш, бакыр кебек затлы металларны чыгару процессы

2) *тех.* Өске катламының чыдамлыгын арттыру максаты белән, аз углеродлы корычның өстен югары температура шартларында углеродка туендыру

3) *геол.* Тау токымының өлешләре минераль матдәләр белән үзара берегү күренеше

**ЦЕМЕНТА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Цементация үткәрү. *Корычны цементацияләү*

**ЦЕМЕНТЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **цементлау**. *Тауның яңгыр сулары агып төшә торган ягы, яртылаш цементланып, сусаклагычка әвереләдерелгән – Гибралтарда табигый су чыганаклары житешми.* Р.Мостафин

2) Көчле басым нәтиҗәсендә тыгызланып цементка әйләнү. *Утырган минерал һәм токым кисәкчекләре тыгызлана һәм өстәрәк яткан катлаулар басымы астында цементлана.* Башлангыч география курсы

**Цементлана башлау** Цементланырга тотыну

**Цементланып бетү** Тулысынча, нык цементлану

**ЦЕМЕНТЛА́У** *ф.* 1) Грунтларны, таш һәм бетон корылмаларны ярыкларына һәм куыш җирләренә цемент измәсе тутырып ныгыту, цемент белән катыру. *«Татнефть» берләшмәсе бүген моннан егерме еллар элек бораулаган скважиналарны цементлау чарасына керeште.* Ә.Маликов

2) Цемент измәсе белән каплау. *Төзелеш эшчеләре, идәннәрне цементлап, резин паласлар җәяләр.* Сарман

3) *күч.* Берләштерү, туплау, ныгыту. *Минем аның колхозчыларны төрле мәсьәләләр буенча кабул иткән чакларында күп күргәнем булды. Төчеләнмәс, язса – язга, килешсә – көзгә, дигәндәй, буш вәгъдәләр бирмәс. Вәгъдәсе көненә-сәгатенә тикле конкрет булыр. Кешеләрнең ышанычын шул цементлый.* Б.Камалов

**Цементлап килү** Күптәннән һәм эзлекле рәвештә цементлау. *Югары катламга омтылу ир белән хатынның араларын цементлап килә иде.* Х.Камалов

**Цементлап кую** Тиз генә яки алдан цементлау. *Бирeдән чүпләрне җыйганнар, һәйкәл янындагы берәү аударып киткән кирпеч баганаы яңадан бастырып цементлап куйганнар.* Безнең Чирмешән

**Цементлап чыгу** Тулысынча, башыннан ахырына кадәр цементлау. *Ә менә бина тирәсен цементлап чыгу, вентиляция һәм янгын сигнализациясе урнаштыру эшләренә керешмәгәннәр әле.* Әлки хәбәрләре

**Цементлый башлау** Цементларга тотыну

**ЦЕМЕНТЛЫ** *с.* 1) Цемент кушылган. *Бүрәнәләрнең бик черек җирләренә цементлы балчык сылап, тактатокта кадаклаштырдылар.* Ф.Яруллин. *Абый, цементлы измәне завод алып кайтамы?* К.Кәримов

2) Цемент тутырылган, цемент төялгән. *Шул атаклы югары уку йортында белем алган чорда да, цементлы, утынлы вагоннарны бушатып, ишле гаиләбезгә матди яктан ярдәм итеп тордым.* Ирек мәйданы. *Цементлы капчык*

**ЦЕНЗ** *и. лат.* 1) *тар.* Социальсәяси, хәрби, салым түли алу дәрәҗәләрен билгеләү максаты белән, билгеле период саен Борынгы Рим гражданнарының милекләрен исәпкә алып үткәрелгән җанисәп

2) Нинди дә булса сәяси хокуклардан файдалану мөмкинлеген чикли торган шарт. *Әлеге дә баягы, безнең заманнарда яшь цензы бар иде: әдәби семинарларга, конференцияләргә яше 35 тән артмаган, чынлап та яшь язучыларны чакыралар иде.* Марс Шабаев. *Белем цензы. Милек цензы*

3) *махс.* Предприятиене билгеле исемлеккә, реестрга кертү өчен кирәкле шарт

4) Инглиз телле илләрдә: халык санын алу, җанисәп

**ЦЕ́НЗОР** *и. лат.* 1) *тар.* Борынгы Римда гражданнарның милкен бәяләү эшләрен башкаручы, салым түләү һәм җәмгать әхлагын күзәтүче вазифалы зат

2) Цензура (*3 мәгъ.*) эшен башкаручы вазифалы зат. *Бәлки, цензор Пинегин да: «Татарларның барысы да диярлек үзенчә укый-яза белә», – дип, юкка гына язмагандыр?* Т.Әйди. *Вафаны цензор чакыртып алган иде.* Р.Зәйдулла

**ЦЕ́НЗОРЛЫК** *и.* Цензор (*2 мәгъ.*) вазифасы, хезмәте. *Хәтта, штатта андый белгечлек каралмагач, цензорлык вазифасын да үзебезгә башкарырга туры килде.* Ә.Рәшит

**ЦЕНЗУ́РА** *и. лат.* 1) *тар.* Борынгы Римда цензор (*1 мәгъ.*) вазифасы

2) Сәнгать әсәрләрен, массакүләм мәгълүмат чараларын яки почта аша җибәрелгән хатларны дәүләт тарафыннан күзәтү системасы; шундый күзәтүне башкаручы учреждение. *Анысы СССРда беркайчан да өзелеп тормаган, цензура тамыр җәя барган саен, елдан-ел көчәйгән генә.* А.Тимергалин

3) Рәсми хакимият тарафыннан зарарлы яки кирәкмәгән дип табылган идеяләр һәм фикерләрнең таралуына юл куймау максаты белән, киң массаларга тараласы мәгълүматның эчтәлеген алдан тикшерү. *Бу документлар буенча, югарыда әйтелгән чараларга өстәп, басма продукциягә цензура кертелергә, рәсми булмаган басмалар бөтенләй тыелырга тиешле булып чыкты.* И.Хуҗин

**ЦЕНТ** *и. ингл.* АКШта һ.б. кайбер илләрдә төп акча берәмлегенең йөздән бер өлешенә тигез булган вак акча. *Доллар түгел, ә бер цент өчен тамагы карлыкканчы сатулаша.* А.Хәсәнов

**ЦЕ́НТНЕР** *и. нем.* Метрик үлчәү системасында 100 килограммга тигез булган авырлык үлчәү берәмлеге. *Печәнгә төшкәндә халык бик өзелә дип, Хөсәен биш-алты центнер бодай калдырткан иде.* А.Гыйләҗев

**ЦЕ́НТНЕРЛАП** *рәв.* 1) Центнерга якын; центнер чамасында. *Йорт башыннан икешәр центнер гына җыйганда да өч йөз дә алтмыш центнерлап әйбер җыелырга тиеш.* В.Нуруллин. – *Гектарыннан якынча 250 центнерлап*

*яшел масса җыеп алабыз, – ди Ленар.* Яңа тормыш

2) Центнер исәбе белән үлчәп. *Дөрес, миңа балык килолап түгел, центнерлап, тонналап кирәк.* Ә.Еники. *Миңа гына каныктың инде, усалларны күрмисең шул. Алар центнерлап тотса да ярый, сүз әйтүче юк...* З.Мурсиев

**ЦЕ́НТНЕРЛЫ** *с.* Бер яки билгеле центнер авырлыгындагы. *Ниһаять, хөрмәтле Иван Ивановичның кура җиләгедәй кызарган центнерлы гәүдәсе карлыгач булып ләүкәдән очып төшә.* А.Гыйләҗев

2) Билгеле центнер сыешлы. *Арбада ягулык тутырылган өч центнерлы мичкә.* Г.Галиев

3) Центнерлар белән үлчәнә торган

**ЦЕНТРАЛ** *и. рус тар.* 1917 елга кадәр Россиядә башлыча сәяси тоткыннар өчен билгеләнгән үзәк каторга төрмәсе. *Әйтик, күп кенә җырларга кергән Владимир централы Норвегия төрмәләре белән, Ивановодагы колонияләр Бөекбритания төрмәләре белән --- элемтәгә кергәннәр.* Татарстан яшьләре

**ЦЕНТРАЛИЗМ** *и. рус сәяси* Җирле органнарның үзәккә буйсынып, аның күрсәтмәләре белән эш итүдән гыйбарәт идарә итү яки оештыру системасы; үзәкчелек. *Әмма ул акчалар һаман да коммунистлар режимындагы централизм методы белән килә.* Р.Зарипов

**ЦЕНТРАЛЬ** *и. нем.* 1) Төп, үзәк магистраль. *Җылылык магистрале*

2) Кушма сүзләрдә шул ук мәгънәдә икенче компонент. *Гидроцентраль*

**ЦЕНТРИЗМ** *и. рус сәяси* Реформизм белән консерватизм юнәлешләре, суллар белән уңнар арасындагы урынны, урталык позициясен алырга тырышкан сәяси агым. *Русия ягы белән сөйләшүләр вакытында Татарстан делегациясенә прагматизм һәм центризм ярдәм итте.* Р.Хәкимов

**ЦЕНТРИСТ** *и. рус сәяси* Центризм тарафдары. *Демократларга иярмәгез, центристларга ышанмагыз, коммунистларны идән астыннан чыгармагыз, либералларга таянмагыз, милләтчеләрне тыңламагыз!..* К.Кәримов

**ЦЕНТРИ́СТИК** *с. сәяси* Центризмга һәм центристларга хас булган. *Центристик сәясәт. Центристик позиция*

**ЦЕНТРИСТЛЫК** *и. сәяси* 1) *к.* **центризм**. *Бүгенге шартларда центристлык юнәлешендәге иҗтимагый берләшмәләрнең яшәп килүе аеруча мөһим.* Ватаным Татарстан

2) Центрист булу. *Депутатның центристлыгы*

**ЦЕНТРИФУ́ГА** *и. нем. тех.* 1) Катнаш матдәләрне үзәктән куу көче тәэсире белән состав өлешләренә аера торган аппарат. *Пробиркаларны тиешле язулар белән урнаштыргач, өстәлләрне җыештырып, центрифуганы ычкындырдым да --- Фәнүзәнең сәер карашын абайлап туктап калдым.* Ә.Баян. *Кул белән центрифуганы әйләндерәм.* А.Гыйләҗев

2) Космонавтларны күнектергән вакытта үзәктән куу көче белән организмга көчле физик тәэсир барлыкка китерә торган җайланма. *Севчук, тәрәзәдән башын тыгып, бермәл, үзен центрифугада сынарга әзерләнгәндәй, башын боргалап торды, аннары яңадан өстәл янына килде.* З.Фәтхетдинов. *Бер кызны центрифуга моделенә утырттылар да әкрен генә әйләндерә башладылар.* Р.Зарипов

**ЦЕНТРИФУ́ГАЛАУ** *ф.* Центрифуга ярдәмендә катнаш матдәне аерым состав өлешләргә аеру, аерту. *Кайчакта төрле тыгызлыклы сыеклыкларны, мәсәлән, каймакны сөттән центрифугалап аералар.* Химия

**ЦЕРЕБРАЛЬ** I *с. мед.* Ми эшчәнлеге белән бәйле. *Церебраль параличлы балалар бездә күп икән.* Г.Хәсәншина

**ЦЕРЕБРАЛЬ** II *с. лингв.* Тел очы каты аңкауга табан күтәрелеп, бераз гына артка бөгелеп ясала торган (тартык авазлар тур.)

**ЦЕРЕМОНИАЛ** *и. лат.* Берәр йоланы, мәрасимне үткәрү өчен рәсми кабул ителгән, гадәттә үтә тантаналы төстәге тәртип. *Инсценировканы уздырдым ---, аерым моментлар искиткеч бер җанлылык белән үттеләр: --- фронтка китә торган парад церемониалы, Николайның смотры көтелгәннән артык матур иделәр.* Ш.Усманов

**ЦЕРЕМОНИАЛЬ** *с.* 1) Церемониал белән бәйле, шуңа караган. *Илләр, дәүләтләр башлыкларының дуслыгы – рәсми, церемониаль күренеш яки реклама, абруйлану чарасы – шуннан ары берни түгел.* М.Мирза

2) Билгеле бер церемониал буенча үткәрелә торган. *Церемониаль маршны ишеткәч тә бии башлаган кавалерия аты кебек, Галим Урманов та, урман өсләрендә яңгырап торган ерактагы пулемёт тавышларын ишеткән саен, кызурак атлады.* Г.Әпсәләмов

**ЦЕРЕМОНИЙМЕ́ЙСТЕР** *и. нем. тар.* 1917 елга кадәрге Россиядә югары сарай чиннарының берсе: церемониалның үтәлешен күзәтеп торучы һәм сарайдагы церемонияләр белән җитәкчелек итүче шундый чиндагы кеше

**ЦЕРЕМО́НИЯ** *и. лат.* 1) Нинди дә булса йола, акт, тантана үткәрүнең кабул ителгән, билгеләнгән тәртибе; шул йола, акт, тантана үзе; мәрасим. *Юбилей тантанасы Вәлиуллиннар яшәгән нигездәге йорт капкасына мемориаль такта кую церемониясе белән башланып китте.* Т.Нәҗмиев

2) *сөйл.* Үз-үзен тотуда, мөгамәләдә үтә тәкәллефле кешегә хас шартлы кыланышлар, кагыйдәләр; мөгамәләдәге, үз-үзен тотудагы ясалмалылык. *Ханым, йөзенә ясалма елмаю чыгарып, тәртип белән һәркайсын язды, ниндидер кәгазьләр бирде, яхшы ял теләде, чәй бүлмәсенә кереп чәй эчәргә тәкъдим ясады. Бу церемония бик озакка сузылды.* Д.Каюмова

**ЦЕХ** *и. нем.* 1) Сәнәгать предприятиесенең төп җитештерү берәмлеге: бер төр эшләнмәләр чыгара торган бүлек. *Цех мастеры, элекке тормышта коммунистик хезмәт ударнигы булып йөргән Кәримов, тирә-якка каранакарана, һәм «Алтын чәч» ариясеннән кайсыдыр өлешен борын эченнән генә көйли-көйли, завод идарәсенә юл алды.* Я.Шәфыйков. *Станоклар шауладылар цехларда.* Р.Мингалим

2) Шундый бүлек урнашкан бина. *Караклар цех түбәсенә менәләр.* Р.Кәрами

3) Шул бүлектә эшләүче кешеләр. *Коючылар цехын фаҗига тетрәтте.* Н.Хәсәнов. *Кыскарттылар. Цехыбыз белән киттек. Базарга чыгарга мәҗбүр булдым.* В.Нуриев

4) *тар.* Урта гасырларда Көнбатыш Европа шәһәрләрендә бер үк профессияле һөнәрчеләр оешмасы. *Башмакчылар цехы*

**ЦЕХКОМ** *и. рус сөйл.* Цехның профсоюз комитеты. *Цехком утырышы билгеләгән идек.* Т.Әйди

**ЦЕХЧЫЛЫК** *и. сөйл.* Үз профессиянә генә бикләнгәнлек, профессиональ тарлык, чикләнгәнлек. *Цехчылыкка каршы көрәш*

**ЦИАН** *и. нем. хим.* Углерод белән азот кушылмасыннан гыйбарәт әче исле төссез агулы газ. *Этилацетосеркә эфиры белән циан кислотасы арасында*

*бара торган реакциянең тигезләмәсен язарга.* Органик химия

**ЦИАНЛА́У** *ф. махс.* 1) Рудадан алтын һәм көмешне цианлы эремә ярдәмендә эретү ысулы белән алу

2) Корыч әйберләрнең ныклыгын арттыру өчен, аларның өске катлавын азот һәм углерод белән туендыру

**ЦИАНЛЫ** *с. хим.* Циан катнашкан, составында циан булган. *Шул ук көнне тагын бер хәбәр яңгырады: кемдер Америка сенатына, гап-гади конвертка салып, ак порошок җибәргән, белгечләр аның цианлы калийдан 6 мең тапкыр агулырак рицин икәнен ачыклаганнар.* Татарстан яшьләре

**ЦИВИЛИЗА́ТОР** *и. лат.* Цивилизация урнаштыручы. *Геноцид – цивилизаторлар бакчасы җимеше.* Р.Зарипов

**ЦИВИЛИЗА́ТОРЛЫК** *и.* Цивилизатор булу. *Авторның әйтүенә караганда, яңа хезмәттә төрки халыкларның дөнья тарихында тирән эз калдырган цивилизаторлык ролен һәм казанышларын ачуга, киң җәмәгатьчелеккә җиткерүгә аеруча зур әһәмият биреләчәк.* Ә.Шәрипов

**ЦИВИЛИЗА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Теге яки бу иҗтимагый-икътисади формация ирешкән иҗтимагый үсеш, матди һәм рухи культура дәрәҗәсе. *Ләкин моның тамыры мөселманлык чорыннан да ераккарак – борынгы Мисыр һәм гомумән борынгы цивилизация заманнарына сузыла.* Н.Фәттах. *Бу идеология Россия хакимиятенең дә төрки цивилизациягә булган мөнәсәбәтен тамырдан үзгәртте.* М.Хәсәнов

2) Хәзерге дөнья мәдәнияте һәм аңа хас техник казанышлар. *Тик Ходай бирмәгән бәхетне цивилизация белән генә алыштырып булмый икән ул барыбер.* З.Мифтахов. *Телефон да, газ да юк – цивидизациянең әсәре дә юк анда*

**ЦИВИЛИЗА́ЦИЯЛӘНҮ** *ф.* Цивилизацияле булып китү; тагын да цивилизациялерәк булу

**ЦИВИЛИЗА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Цивилизацияле итү; цивилизация дәрәҗәсен тагы да күтәрү

**ЦИВИЛИЗА́ЦИЯЛЕ** *с.* Цивилизация (*2 мәгъ.*) урнашкан; мәдәниятле, югары үсешле. *Чын исеме Ләүзә, әлбәттә, ләкин тәкәббер кыз татар исеменнән ояла шикелле, аңа булгач, Европача булсын, янәсе цивилизацияле илләрдәгечә.* З.Мурсиев

**ЦИВИЛИЗА́ЦИЯЛЕЛЕК** *и.* Цивилизацияле булу. *Ә башка халыкларның законлы хокукларын танырга теләмәү элементар цивилизациялелекнең булмавы, халыкара хокукны санга сукмау һәм кешелек дәрәҗәсен кимсетү турында гына сөйли ул.* Р.Вәлиев

**ЦИВИЛЬ** *с.* 1) Гражданлык җәмгыятенә караган, хәрби, гаскәри булмаган; штатский. *Аның каравы уяну белән, Гыйлемдар өстәлдәге Шүрәле статуэткасы торган урында ауган агачка утырып ял итүче берәүнең төсле фоторәсемен күрде. Ачык төстәге цивиль костюм кигән бер ир-егет.* А.Тимергалин. *Ул җыйнак цивиль киемнән иде, пөхтә, тыйнак кеше иде.* Ф.Бәйрәмова

2) Цивилизация (*2 мәгъ.*) таләпләренә туры килә торган

**ЦИГАЙ** *и. нем.* Нечкә йонлы сарык токымы

**ЦИГЕ́ЙКА** *и. рус* < *нем.* **1.** 1) Махсус эшкәртелгән цигай токымлы сарык мехы

2) *сөйл.* Шундый мехтан тегелгән тун. *Кыз өстендә цигейка*

**2.** *с. мәгъ.* Шул мехтан тегелгән, эшләнгән. *Җитмеш бишәр литр салсаң, морадыңа ирешәсең, чем кара тунлы да буласың, чатлама суыкларда да өшетми торган цигейка бүреклек тә сәрмая чыгар.* Т.Әйди

**ЦИКЛ** *и. гр.* 1) Нәрсәнеңдер төгәлләнгән башкарылышын, үсешен тәшкил иткән ниндидер күренешләр, процесслар, эшләр һ.б. җыелмасы. *Ләкин мөселман календарендагы кәбисә елларның, XX гасырда без яшәгән календарьдагы кебек дүрт елга бер кабатланмыйча, утыз еллык цикл белән алмашынуы мәсьәләне шактый катлауландыра.* А.Тимергалин. *Алмаш ток циклы. Эчке янулы двигатель циклы*

2) Үзара бәйләнешле, эзлекле рәвештә бер-бер артлы кабатлана, башкарыла, үтәлә торган күренешләр яки дисциплиналар җыелмасы. *Лекцияләр циклы*

3) Уртак тема, катнашучылар һ.б. белән үзара бәйләнгән бер үк жанрдагы әдәби, музыкаль әсәрләр җыелмасы. *Соңгы елларда ул [Т.Миңнуллин] авыл эте турында балалар сәхнәсе өчен тулы бер пьесалар циклы иҗат итте: «Авыл эте Акбай», «Акбай һәм Сарык малае» ---.* А.Әхмәдуллин. *Гомеренең соңгы елларында ул Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» шигырьләр циклына мөрәҗәгать итә.* К.Гыйззәтов

**ЦИ́КЛИК** *с. кит.* 1) Цикллап кабатлана торган; цикллы. *Бу табигый, чөнки татар шигърияте тарихында мәгълүм циклик үсеш кичергән фикер поэзиясе хәзер чын мәгънәсендә югары баскычка күтәрелде.* З.Мансуров. *Бу системада «үсеш», «уку», «камилләшү» төшенчәләре этикага нигезләнгән циклик процесслар буларак аңлатыла.* Фән һәм тел

2) Цикл (*3 мәгъ.*) барлыкка китергән, цикл тәшкил иткән. *Д. Фәтхинең «Алтын тайга трагедиясеннән» поэмасында композиция сонатаның циклик формасы белән охшаш.* Н.Юзиев

3) *хим.* Төзелеше, структурасы боҗра, балдак кебек булган. *Составына азот кергән кушылмалар арасында циклик төзелешле матдәләр бигрәк тә күп. Глюкоза, рибоза, дезоксирибозаның циклик молекулаларына кислород атомнары кергән кебек, цикллар составына углерод атомнары белән берәттән азот атомнары да кергән кушылмалар аеруча әһәмиятле.* Органик химия. *Циклик элементлар группасы*

**ЦИ́КЛЛАП** *рәв.* Цикллар белән, цикл-цикл итеп. *Аның «Хәрефләр ислахы», «Имла вә хоруф мәсьәләсе», «Матбагачылыкта тәрәккый» һ.б. исемдәге күпсанлы мәкаләләре цикллап басыла.* М.Мәһдиев

**ЦИ́КЛЛАУ** *ф. махс.* Цикллап эшләү, эшне циклларга бүлү. *Ташкүмер чыгаруны цикллау*

**ЦИ́КЛЛЫ** *с.* 1) *к.* **циклик** (*1 мәгъ.*). *Тарихта цикллы кабатланулар турындагы фикере белән Ибне Халдун XX гасырның күренекле тарихчысы Лев Гумилёвның теориясен дә хәтерләтә.* А.Тимергалин

2) Җитештерү циклларына нигезләнгән, цикллылыкны (*2 мәгъ.*) саклаган. *Цикллы график. Цикллы метод белән эшләү*

**ЦИ́КЛЛЫЛЫК** *и.* 1) Цикллы (*1 мәгъ.*) булу, цикллы характерда булу. *Шул ук вакытта үреп ясау безне Шәрык сәнгатенә юллый, үзендә тормышның кабатлану, цикллылык потенциалын туплый.* М.Хәбетдинова

2) Җитештерүне оештыруда катгый рәвештә график буенча үтәлергә тиешле циклларлардан торган система

**ЦИКЛОН** *и. гр. метеор.* Үзәгендә түбән атмосфера басымы булган үтә зур (йөзләгән километрдан алып берничә мең километрга кадәр) диаметрлы вертикаль күчәрле атмосфера өермәсе рәвешендәге һава массасы. *Әллә кайсы гына океаннан циклон килә, диделәр.*

Г.Әпсәләмов. *Циклон булгач, антициклоны да килә инде аның.* А.Хәмзин

**ЦИКЛОНЛЫ** *с.* 1) Циклон характерында булган; циклон урнашкан. *Бүген республика территориясендә циклонлы һава торышы хөкем сөрә.* Әлки хәбәрләре

2) *махс.* Ягулыкны вертикаль яки горизонталь утлык алдындагы газ-һава өермәсендә яндыруга нигезләнгән. *Циклонлы утлык*

**ЦИКЛОП** *и. гр.* 1) *миф.* Борынгы грек мифологиясендә: маңгай уртасында сыңар күзе булган зур гәүдәле зат. *Бу сюжет икенче бер яктан да игътибарга лаек: әкияттәге сыңар күзле Дию карчыгы Гомерның «Одиссея» поэмасындагы Циклопка охшаш.* Л.Җамалетдинов

2) *зоол.* Ишкәгаяклы кыслачыклар семьялыгыннан төче сулыкларда тереклек итә торган сыңар күзле кечкенә ерткыч су хайваны. *Әллә кайсы гына океаннан циклоп килә, диделәр.* Г.Әпсәләмов

**ЦИКЛОТРОН** *и. гр. физ.* Электр корылмалы кисәкчекләрнең хәрәкәтен тизләтү аппараты. *Ибраһимов реакторда, циклотронда төш нурланышы алган материалларны өйрәнергә карар кыла һәм фараз итү, исәпләү, тәҗрибәләр ясауга баштанаяк кереп чума.* Т.Әйди

**ЦИ́КЛЯ** *и. нем.* Агач өслекне тигезләү, шомарту өчен йөзе кайралган юка корыч пластинка рәвешендәге кул коралы. *Паркет циклясы*

**ЦИКО́РИЙ** *и. гр. бот. к.* **һиндыба**. *Ул солы, арпа яисә цикорий кофесын безнең өйдә эчкән кеше булмады.* Р.Гаязетдин

**ЦИЛИНДР** *и. гр.* 1) *мат.* Турыпочмаклыкны кайсы да булса бер кыры тирәсендә әйләндерүдән килеп чыккан геометрик җисем. *Эчендәге энергиясе бүленеп чыккан күләм, рәсемдә күрсәтелгәнчә, бер берәмлек биеклегендәге цилиндр күләменең яртысына --- тигез.* Төзү материаллары

2) *тех.* Шул җисем формасындагы деталь яки җайланма. *Цилиндрның берсенең поршене аска төшкән вакытта, газ ачылып китә дә, шуңа баетылган ягулык килеп керә.* М.Мәһдиев

3) Шул формадагы биек, каты, тар кырыйлы ирләр эшләпәсе. *Уйнарсың Чемберленны да, ләкин аның өчен цилиндр я булмаса зур эшләпә кирәк.* Т.Гыйззәт. *Ул цилиндр кигән, кара фракта, трость тоткан.* Г.Каюмов

**ЦИЛИ́НДРИК** *с.* Цилиндр рәвешле, цилиндр формасындагы. *Безнең мондый стенаны сылаганыбыз юк. Исәпләп чыгаруы да авыр, үзе конус сыман, үзенең цилиндрик өлеше дә бар, шарга охшаган диярга дә була.* К.Тимбикова

**ЦИЛИ́НДРЛЫ** *с.* 1) Цилиндры булган. *Ике йөк машинасына алты цилиндрлы двигательләр һәм автомат тапшыру тартмалары куелган.* Ватаным Татарстан

2) Башына цилиндр (*3 мәгъ.*) кигән. *Цилиндрлы ирләр*

**ЦИМБАЛ** *и. гр. муз.* Агач таяклар яки кечкенә чүкечләр белән сугып уйнала торган, яссы тартма формасындагы кыллы музыка коралы. *Өч кыллы думбра һәм монгол цимбалының кардәше булган җингинур уен кораллары хәзерге калмык халык уен кораллары оркестрларында файдаланыла.* Яңарыш

**ЦИМБАЛЧЫ** *и.* Цимбалда уйнаучы

**ЦИНАНДА́ЛИ** *и.* Грузиядәге авыл исеме белән аталган ак шәраб сорты; шул сорттагы шәраб. *Шәраблары да сусынны басар өчен генә: «Цинандали», «Мукузани», «Алазан үзәне», тагын әллә ниләр.* Р.Вәлиев

**ЦИНИЗМ** *и. гр. кит.* 1) Борынгы Грециядә әхлакый иҗтимагый нормаларны кире каккан, гадилеккә, кире табигатькә кайтуга өндәгән фәлсәфә мәктәбе. *Цинизм тарафдарлары*

2) *күч.* Бар кеше тарафыннан хөрмәт ителгән нәрсәгә кимсетүле караш, ачык оятсызлык, әдәпсезлек, әхлаксызлык; циниклык. *Күңеле эгоизм, цинизм һәм минминлек белән, тәне иң әшәке чирләр белән тулы аның.* Г.Әпсәләмов

**ЦИ́НИК** I *и.* 1) *тар.* Цинизм тарафдары. *Циниклар фәлсәфәсен мин тыңлый алмыйм.* Г.Әпсәләмов

2) *күч.* Гомумхалык тарафыннан хөрмәт ителгән, олыланган нәрсәгә кимсетеп караучы, әхлаксыз, оятсыз кеше. *Үзең дә артык сноб яки артык циник булмасаң, рәхим ит!* Ялкын

**ЦИ́НИК** II *с.* 1) Цинизм, әдәпсезлек күрсәтә торган (кеше тур.). *Моны Г.Павловский кебек циник сәясмәннәр ачыктан-ачык таный.* Р.Зәйдулла. *Платон [Зубов]ка ул вакытта нибары егерме өч кенә яшь, шуңа карамастан ул алдын-артын салкын канлылык белән нык уйлап эш итүче, битенә дуңгыз тиресе каплаган циник кеше була.* Казан утлары

2) Цинизм белән сугарылган; әдәпсез, әшәке (караш, фикер, сүз тур.). *Оригиналның интонациясе һәм Чайлд тарафыннан күзәтелгән нindидер циник яңгырашы татар вариантында, минемчә, Пушкинга караганда ныграк сакланган...* Казан утлары

**ЦИ́НИКЛАРЧА** *рәв.* Циникка хас булганча, әшәке итеп. *Югыйсә үзләрен бик цивилизацияле кешеләр дип лаф орырга яраталар, циникларча кылануларыннан коскылар келі.* Ш.Алпар

**ЦИ́НИКЛЫК** *и. к.* **цинизм** (*2 мәгъ.*). *Арысланнарны йомыкый, аз сүзле, серле итеп бирүгә караганда, алардагы ихтыяр көчен, интрига-мәкер, тапкырлыкны һәм циниклыкны тирәнрәк ачу әсәрне күпкә кызыклырак, җанлырак һәм, бигрәк тә әһәмиятлесе, аларны тормышчанрак итәр иде.* Т.Әйди

**ЦИНК** *и. нем.* **1.** 1) Химик элемент (Zn), чүкелүгә бирелүчән аксыл күк төстәге металл. *Нитробензолны селтеле тирәлектә цинк белән селте тәэсир итешкәндә аерылып чыккан водород ярдәмендә кайтарган вакытта, башта нитробензол һәм фенилгидроксиламин хасил була.* Органик химия

2) *хәрби* Шул металлдан эшләнгән тартма, әрҗә. *Ике цинк патрон*

**2.** Шул металлдан ясалган. *Газеталарга язмасалар да, ишетеп-белеп торалар, Әфган якларыннан цинк табутлар белән бергә коточкыч хәбәрләр кайта...* Р.Габделхакова

**ЦИ́НКЛАНУ** *ф. төш. юн. к.* **цинклау**. *Чөнки түбәсе гомерлек итеп цинкланган калай белән ябылган, карнизләре киң: бәреп яуган яңгыр вакытында да стеналарына су тиярлек түгел.* В.Нуруллин

**ЦИ́НКЛАУ** *ф.* 1) Цинк белән туендыру

2) Цинк белән каплау, цинк йөгертү

**Цинклап чыгу** Булган берсен цинклау

**ЦИ́НКЛАУЧЫ** *и. махс.* Цинк йөгертүче эшче

**ЦИ́НКЛЫ** *с.* Составында цинк булган. *[Янгантау] Күкертле, цинклы һәм радонлы чишмәләре белән дан тота.* Г.Исхакова

**ЦИНКО́ГРАФ** *и. рус махс.* Цинкография белгече

**ЦИНКОГРА́ФИЯ** *и. нем.-гр. махс.* 1) Типография өчен цинк клишелар эшләп чыгару, ясау ысулы

2) Шундый клишелар эшләнә торган предприятие яки цех. *Бу корпуска матбагаӊың гәзит, журнал һәм хәреф җыю цехлары, цинкография, стерео-*

*тип бүлеге кебек форма хәзерли торган өлешләре куелачак.* Ш.Самат

**ЦИ́ННИЯ** *и. бот. [кеше исеменнән]* Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан төрле төстәге чәчәкле декоратив үлән үсемлек. *Нинди генә чәчәкләр юк бит аның бакчасында: кашкарый, цинния, дәлия, флокслар, лаләләр, гладиолуслар һ.б.* Шәһри Казан

**ЦИРК** *и. лат.* 1) Акробатика, эквилибристика, жонглёрлык, клоунлык, хайваннарны өйрәтү һ.б.ны эченә алган театр сәнгате төре. – *Таныш булыйк. Элекке цирк артисты, хәзер кара эшче Крыймов, – диде.* А.Тимергалин. – *Сез циркны яратасызмы? – дип сорады ул.* И.Зарипов // Шул сәнгать төрендәге театраль тамаша. *Бераздан колхоз ударникларын шәһәргә цирк карарга алып бардылар.* Н.Әхмәдиев

2) Акробат, жонглёр, клоун һ.б.ш. катнашында тамашалар оештыра торган учреждение, тамаша предприятиесе. *Кичә Җәүдәт Фәйзине китереп салдылар. Йөрәк. Палаталары – дүрт кешелек. --- Берсендә цирк директоры ята.* Г.Әпсәләмов. *Мин, булдыра алсам, циркта эшләр идем.* А.Гыйләҗев

3) Шундый тамашалар үткәрелә торган ареналы, амфитеатрлы һәм гадәттә гөмбәзле бина. *Бу – мәктәп! Цирк аренасы түгел!* Р.Габделхакова. *Бу юлы ул мине цирк янында көтеп тора иде.* З.Мәхмүди

4) *геогр.* Текә тау битләвенең югары өлешендә карлы климат шартларында кечерәк бозлыклар, җыелып калган карлар һәм физик таркалу тәэсиреннән хасил булган текә кырыйлы һәм сөзәкләнеп кергән төпле ярымтүгәрәк формадагы табигый иңкүлек. *Циркка төшү. Цирк төбендәге күл*

5) *махс.* Ай рельефында уртасындагы таучыгы булмаган тигез төпле кратер. *Айның циркларын өйрәнү*

6) *сөйл.* Мәгънәсез, абсурд, буталчык вакыйга, факт һ.б.ш. кыланыш. – *Бу нинди цирк тагы? – дип кычкырабыз. – Бу, – ди Миргалим, – автоматизация!* Р.Батулла

**ЦИРКОН** *и. нем. < фар.* Составында цирконий булган минерал. *Табигатьтә тышкы тәэсирләргә чыдам минераллар да очрый (мәсәлән, алмаз, корунд, циркон һ.б.).* Төзү материаллары

**ЦИРКО́НИЙ** *и. лат.* Химик элемент (Zr), көмештәй ак металл. *Теге чакта цирконий, борий, германий тимерләрен ничек озаткан иде бит Польшага.* Г.Гомәр

**ЦИ́РКУЛЬ** *и. лат.* Әйләнә сызу һәм сызыкларның озынлыгын үлчәү өчен як-якка аерыла торган ике япьле сызым коралы; җәзбә. *Аннары бик тырышып линейка, циркуль белән сызып, җилем белән ябыштырып, калькадан очлы калфак ясады.* М.Маликова

**ЦИРКУЛЯР** I *и. лат.* **1.** Югары оешмалардан түбән оешмаларга яки кул астындагы вазифалы кешеләргә җибәрелә торган директив күрсәтмә, боерык. *Нотага карамыйча урам көе уйный алмастай дипломлылар атказанган артист булып йөри, ә мин партия номенклатурасының эчке циркулярына туры килмим.* К.Кәримов. *Губерналарга мәркәздән циркулярлар оча.* Р.Зарипов

**2.** *с. мәгъ.* Шундый боерык булган; шул күрсәтмә буларак таратыла, төшерелә торган. *Нәтиҗәдә комиссариат каршындагы татар телен гамәлгә кую комиссиясе, татар телен өйрәнүнең кирәклеген аңлатып, циркуляр хат белән чыгарга мәҗбүр була.* З.Кириллова

**ЦИРКУЛЯР** II *с.* 1) Кискеч коралы түгәрәк формада булган. *Чөнки каралтының урта бер җирендә, җан өзгеч тавышлар чыгарып, циркуляр пычкы үкерә иде.* З.Мифтахов

2) Берьюлы һәр яктан да су сиптерә торган. *Ял итүчеләр душ бүлмәсен, бигрәк тә Шарко, циркуляр душны үз итәләр.* Ватаным Татарстан

**ЦИРКУЛЯ́РКА** *и. рус сөйл.* Циркуляр пычкы. *Кичә генә, тагы кайдандыр сүтеп, электромотор алып кайткан. «Шунардан циркулярка ясап, сине тураклыйм», – ди.* З.Мурсиев

**ЦИРКУЛЯ́ЦИЯ** *и. лат.* Инде үтелгән бер үк ноктага кайта-кайта, йомык маршрут, йомык траектория буйлап хәрәкәт итү процессы. *Ә насослар системасы өзлексез циркуляция һәм фильтратның парга әйләнүен тәэмин итү өчен мөһим.* Кызыл таң

**ЦИ́СТА** *и. гр. биол.* Уңай булмаган шартлар туганда яки яшәү циклының билгеле чорында кайбер беркүзәнәкле организмнарның саклагыч тышча барлыкка килү белән характерлана торган вакытлыча тереклек итү формасы; шул тышча үзе. *Цистаны терлек йоткан очракта, ул аның эчәклегенә эләгә, шунда аның тышчасы эри, паразит эчәк веналары аша бавырга үтеп кerә һәм җенси өлгерә.* Биология

**ЦИ́СТАЛАШУ** *и. биол.* Уңайсыз шартларда циста формасына керү. *Күп кенә иң түбән төзелешлеләрнең мөһим биологик үзенчәлеге – цисталашу.* Биология

**ЦИСТЕ́РНА** *и.* 1) Су һәм башка сыекчалар саклау өчен зур резервуар. *Мин аларны мичкәләр дигән идем, теге инженер абый әйтә, алар – цистерналар, ди.* А.Алиш // Нефтебазаларда, төрле сәнәгать предприятиеләрендә һ.б.ш.да нефть һәм нефть продукциясен саклый торган (гадәттә цилиндрик формадагы) зур сыешлык. *Нефть продуктлары саклана торган зур-зур цистерналар урнашкан әлеге предприятие базасында һәм биш ягулык салу станциясендә янгын куркынычсызлыгын саклауга алар һәрчак тулы әзерлектә булырга тиеш.* Әгерҗе хәбәрләре

2) Шундый резервуары булган вагон, автомобиль һ.б.ш. *Барлык юлларда нефть цистерналары һәм... ашлык төялгән вагоннар.* Г.Әпсәләмов. *Кинәт полиция кордоны аша цистернага охшашлы яшел машина мәйданга узды.* М.Юныс

**ЦИСТЕ́РНАЛЫ** *с.* Цистерна белән тәэмин ителгән, цистернасы булган. *Рәсемнәр арасында игътибарымны авыл юлында туктаган цистерналы машина җәлеп итте.* А.Тимергалин. *Хәзер теге егет килеп җитәргә тиеш. Рәшит. Нефтьчеләрнең урман буендагы иләмсез зур цистерналы объектын саклаучы Рәшит.* Җ.Юныс

**ЦИСТИТ** *и. гр. мед.* Сидек куыгы ялкынсыну; очык. *Бөергә салкын тигәндә дәваланмасаң, цистит хроник төргә әйләнә.* Кызыл таң

**ЦИТАДЕЛЬ** *и. фр.* Хәрби ныгытма диварлары эчендә мөстәкыйль рәвештә оборона тотарлык итеп төзелгән корылма. *Галимнең раславынча, X–XI гасырларда калага болгарлар киләләр һәм таштан биек манаралы яңа корылма – цитадель торгызып куялар.* Ф.Хуҗин

**ЦИТА́ТА** *и. лат.* Берәр текстан үзгәртмичә китерелгән өзек, өземтә. *Тукай Гали Чокрыйның фикерен цитата рәвешендә генә файдаланган булырга мөмкин.* А.Тимергалин. *Бу цитаталар барысы да Малайзия хөкүмәте җитәкчесе чыгышыннан.* Н.Шәрифуллин

**ЦИТО́ЛОГ** *и. гр.* Цитология белгече. *Цитологлар симпозиумы*

**ЦИТОЛО́ГИК** *с.* Цитологиягә караган, шуның белән бәйле. *Цитологик анализ*

**ЦИТОЛО́ГИЯ** *и. гр.* 1) *биол.* Биологиянең хайван һәм үсемлек күзәнәкләренең төзелеше, химик составы, функцияләре, индивидуаль һәм тарихи үсеше турындагы тармагы. *Бакчаның фән өчен әһәмияте зур. Аның, мәсәлән, ботаника, дендрология, декоратив бакчачылык, субтропик культуралар, көньяк культуралары, цитрус үсемлекләре, техник культуралар, үсемлекләрне саклау кебек махсус бүлекләре һәм физиология, биохимия, цитология, орлыкчылык лабораторияләре бар.* Г.Иделле

2) Фәнни тикшерү, диагноз кую һ.б. максат белән ясалган күзәнәк анализы. *Цитология нәтиҗәләре*

**ЦИ́ТРА** *и. нем.* Фигуралы формадагы тартма рәвешендәге чиртмә кыллы уен коралы. *Чех музыканты кызларга нота грамотасын, шулай ук цитра белән мандолинада уйнарга өйрәтә.* Мәдәни җомга

**ЦИТРОН** *и. лат. бот.* Рутачалар семьялыгыннан лимонга охшаган эре җимешле мәңгеяшел субтропик агач яки куак. *Цитрон үстерү*

2) Шул агачның яки куакның сары яки кызгылт сары төстәге үтә калын кабыклы, озынчарак формалы әче яки әчкелт татлы җимеше; агач кавыны. *Цитрон цукаты*

**ЦИ́ТРУС** *и. лат. бот.* Эре сусыл җимешле, калын кабыклы агачлар яки куаклар ыругы һәм шул агачларның, куакларның җимеше (әфлисун, лайм, грейпфрут, лимон, мандарин һ.б.). *Баф – мамык игү, яшелчә, цитрус җимешләре үстерү мәркәзе.* Т.Әйди. *Алар кукуруз, бодай, кузаклылар, шикәр камышы, цитруслар, мамык һәм башка культуралар игәләр.* Материклар һәм океаннар географиясе

**ЦИФЕРБЛАТ** *и. нем.* Нинди дә булса үлчәү приборында үлчәү зурлыкларын белдергән бүлемнәр төшерелгән пластина. *Минемчә, элгән җирдән алып, механизмы белән циферблат арасына күз салганнардыр.* А.Тимергалин

**ЦИФЕРБЛАТЛЫ** *с.* Циферблаты булган. *Ханым, сул кулын күкрәк турысына кадәр күтәреп, ябалак күзедәй олы циферблатлы сәгатенә төбәлде.* Ф.Җамалетдинова

**ЦИФР** *и. гар.* Санны белдерә торган график символ, сан билгесе. *Иске гарәп цифрлары... Хәзергечә язылган булса бер хәл, бәлки, Таймас аларны аңлар да иде.* А.Тимергалин. *Башы тулы цифр: гел нольләр дә нольләр...* Ш.Галиев

**ЦИ́ФРЛАШТЫРГЫЧ** *и. тех.* 1) Өзлексез аналог сигналын дискрет цифрлы формага күчерә торган җайланма, дигитайзер

2) Кәгазь битендәге сызымнарны компьютерга кертә торган җайланма; цифрлаштыру җайланмасы

**ЦИ́ФРЛАШТЫРУ** *ф. информ.* Мәгълүматны цифрлы форматка күчерү. *Дәүләт архивы норматив актларны Татарстан Юстиция министрлыгы белән берлектә цифрлаштыра.* Мәдәни җомга

**Цифрлаштыра башлау** Цифрлаштырырга тотыну

**Цифрлаштырып бетерү** Барысын да, булган берсен цифрлаштыру. *Архивтагы документлар цифрлаштырып бетерелде*

**ЦИ́ФРЛЫ** *с.* 1) Цифрлар төшерелгән, язылган. *Ул Шәфи алдына цифрлы кәгазь китереп салды.* Ш.Маннур

2) Цифрлардан торган, цифрлар белән күрсәтелгән. *Цифрлы таблицалар. Цифрлы күрсәткеч. Цифрлы мәгълүмат*

3) *тех.* Мәгълүматны бинар (икешәрле) форматта саклый яки тапшыра торган; дискрет теркәү технологияләрен кулланган. *Кайбер каләмдәшләр видеокамера, цифрлы фотоаппарат кебек «вак-төяк» кенә югалтканнар иде.* Т.Нәҗмиев. *Хәзерге цифрлы технологияләр заманын күз алдына китерегез.* С.Юзеев

**ЦИ́ЦЕРО** *и. лат. типогр.* Типография шрифтларының эре төрләреннән берсе

**ЦО́КОЛЬ** *и. ит.* **1.** 1) *махс.* Бина яки нинди дә булса корылма стенасының турыдан-туры нигез өстенә урнашкан аскы тышкы өлеше. *Цоколь биеклеге. Таш цоколь*

2) Һәйкәл, колонна кебекләрнең нигезе, постамент. *Һәйкәл цоколен мәрмәр белән каплау*

3) *тех.* Электр лампочкасының патронга борып кертелә торган өлеше – калай кидерелгән төплеге

**2.** *с. мәгъ.* Цоколь (*1 мәгъ.*) дәрәҗәсендә, биеклегендә урнашкан. *Гидротехник корылмага, яр читенә, күпер терәгенә, монументаль бинаның цоколь өлешенә кую өчен, гранит кебек ның, салкынга чыдам таш һәм плитәләр кулланыла.* Төзү материаллары. *Банк бинасының цоколь катында урнашкан саунаның януын узып баручылар күреп ала.* Әлмәт таңнары

**ЦУКАТ** *и. пол.* Шикәр ширбәтендә кайнатылган һәм киптерелгән җимеш яки җиләк. *Әзер цукатларны банкада саклыйбыз.* Шәһри Казан

**ЦУКИ́НИ** *и. ит.* Италиядән таралган яшел төсле гади кабакча төре. *Кыяр чәчкән вакытта, цукини, патиссон һәм кабак утыртырга ярый.* Ватаным Татарстан

**ЦУНА́МИ** *и. яп.* Су астында көчле җир тетрәве нәтиҗәсендә океан өстендә барлыкка килә торган үтә биек җимергеч дулкыннар. *Әллә чыннан да 2005 елгы Тын океандагы гаять көчле цунами нәтиҗәсендә Җир шарының күчәре авышканмы?* Р.Зарипов

**ЦЫЛАШТЫРУ** I *ф. лингв.* [ц] һәм [ч] авазларын аермыйча, икесе урынына да [ц] фонемасын куллану. *Хәзәрләр, күрәсең, мишәрләр, себер татарлары, шулай ук карачай-балкарлар, хәзер башлыча Литвада һәм Кырымда сакланган караимнар кебек цылаштырып сөйләшкәннәр.* Р.Әхмәтьянов. *Цылаштырып сөйләве нинди якын үзе – Яңа Чишмә, Аксубай, Чүпрәленең кайбер авылларындагы кебек.* Шәһри Казан

**ЦЫЛАШТЫРУ** II *и. лингв.* [ц] һәм [ч] авазларын аермыйча, икесе урынына да [ц] фонемасын куллану күренеше (мәс., *цәй, пыцак, агац*). *Төрки һәм монгол цылаштыруының генезисы аерым дигән фикер бар.* Р.Әхмәтьянов

# Ч

**ЧАБА** *ы. диал. к.* **чәбә**

**ЧАБАГАЧ** *и.* Кул белән ашлык сугу өчен, озын агач сапка каеш, чылбыр һ.б.ш. ярдәмендә беркетелгән кыска авыр таяктан гыйбарәт примитив эш коралы. *Нәгыймә боларның икәү бергә ындыр табагында чабагач белән ашлык сукканнарын күрде.* Г.Ибраһимов. *Әвен киптерәләр, чабагач белән суктыралар, аннан, суырып, Ташлытау элеваторына озаталар.* М.Мәһдиев

**ЧАБАГАЧЛА́У** *ф.* Чабагач белән ашлык сугу. *Ул ябык ындыр табагында көлтә чабагачлый.* А.Хәлим. *Үз өен үзе бурап кергән, сәке, өстәл, утыргычлар ясаучы балта остасы да ул, сукалап җирен сөрүче, учлап иген чәчүче,ураклап уручы, чабагачлап сугучы да ---.* М.Рафиков

**Чабагачлап алу** Бераз чабагачлау

**Чабагачлап бетерү** Тулысынча чабагачлау

**Чабагачлап тору** Әле, хәзер чабагачлау. *Берәүләре көлтә ташый, икенчеләре чабагачлап тора*

**Чабагачлап чыгу** Башыннан ахырына кадәр, тулысынча чабагачлау

**Чабагачлый башлау** Чабагачларга тотыну

**ЧАБАГАЧЧЫ** *и.* 1) Чабагач белән ашлык сугучы. *Чабагаччылар эшне өйләгә кадәр бетерде*

2) Чабагач ясаучы

**ЧАБАК** *и.* Карпчалар семьялыгыннан эрерәк тәңкәле, канатлары кызгылтрак булган елга балыгы; *русчасы:* **плотва; сорога**. *Инеш тә шул ук: каз-үрдәкләр мыжылдап тора үзендә, ыштан балакларын бот тиңентен сызганган сипкелле малайлар, агач дөмбе белән комырыклардан вак чабакларны, этлиләрне пыркытып чыгарып, җилгәргеч иләгеннән бозып ясалган бәләкәй җәтмәләр белән балык сөзәләр...* А.Гыйләҗев. *Сирәк булса да чиертә балык: гади елга чабаклары, әлбәттә, ваграклар инде, әмма шулпа өчен ярап тора...* А.Тимергалин

◊ **Чабак чаклы** Бик аз, бик кечкенә. *Чабак чаклы гына соңгы өмет Бәргәләнеп ята күлдәвектә.* Г.Морат

**ЧАБАКЛА́У** *ф.* 1) *сөйл.* Учны учка сугып, чап-чап итү, кул чабу. *Сувенирлар эзләп йөргән чакта Гаҗәпләнгән дә кулың чабакла – Сатып тора бергәү киндерәле, Бәп-бәләкәй, чып-чын чабата!* Ш.Галиев. *Элек кул чабаклап биегәндә, трай-та-та әйтә торган булганнар, имеш.* Ф.Яхин

2) Чапылдатып сугу, кыйнау. *Мин инде, карт тиле кебек, җыен да халык алдында тотып чабакладым үзен.* Т.Гыйззәт. *Уңлы-суллы чабаклады гына, Хәл калмады тәмам түзәргә...* Л.Шагыйрьҗан

**Чабаклап ату** Бик нык чабаклау

**Чабаклап җибәрү** Көтмәгәндә чабаклау

**Чабаклап тору** Даими чабаклау; әле, хәзер чабаклау

**Чабаклый башлау** Чабакларга тотыну. *Шәфкать туташы, аның башын күтәреп, яңакларын чабаклый башлады, үзе туктаусыз: «Мәдинә, Мәдинә!» – дип дәште.* Ф.Садриев

**ЧАБАЛАНУ** *ф. диал. к.* **чәбәләнү**. *– Давыл булыр, – диде ул, – алар давыл алдыннан шулай чабаланалар.* Г.Әпсәләмов

**Чабалана башлау** Чабаланырга тотыну. *Өер башы янында гына дүрт эт кар туздырып чабалана башлады.* Р.Батулла. *Теге чабалана, үпкәли, ачулангандай итә.* Т.Галиуллин

**ЧАБАН** I *с. диал.* Ялкау, үшән (ат тур.)

**ЧАБАН** II *и. фар.* Куй һәм сарык көтүчесе. *Шуңа күрә аннан чабаннарга ашамлык һәм төче су алып килә торган ялчы атнага бер яки тагын да сирәгрәк юлга чыга иде.* Т.Әйди. *Көтүләрне кирәк якка борыр өчен, бер чабан да җитә.* В.Имамов

**ЧАБА́Н ЙОЛДЫЗЫ** *и. астр.* Кояш системасындагы Җир төркемендәге планеталарның Кояшка якынлыгы буенча икенчесе; Зөһрә йолдыз; *русчасы:* **Венера**. *Җентекле тикшеренүләр һәм хисаплаулар пластинкадагы бизәкләрнең чын мәгънәсендә мәңгелек календарь булуын: анда Ай һәм Кояш хәрәкәтләре генә түгел, бәлки Меркурий (Су йолдыз, Кече Чулпан, Готарид яки Гыйтар), Венера (Зөһрә, Чулпан, Чабан йолдызы, Эңгер йолдызы, Кәрван кыйран), Марс (Мәрих, Кызыл яки Бакыр йолдыз, Бәһрам), Юпитер (Мөштәри) һәм Сатурнның (Зөхәл, Туфрак йолдыз) хәрәкәтләре дә исәпкә алынуын күрсәтteләр.* А.Тимергалин

**ЧАБАНЛЫК** *и.* Чабан эше, хезмәте. *Әгәр өйләнсәң, яшь кәләшең сине чабанлыкка бүтән җибәрергә теләмәсә, ялгыз башым нишлим инде мин монда?* Т.Әйди

**ЧАБАР** *и. иск.* Атта ашыгыч хәбәр китерүче (йөртүче); атчабар. *Авылдан чыгып күп тә китмәдек, артыбыздан атлы-мылтыклы чабар килеп җитте.* Н.Исәнбәт

**ЧАБАТА** *и. фар.* **1.** Гадәттә юкә, карама кайрыларыннан, шулай ук теленгән каеш тасмаларыннан үреп ясалган баулы сай аяк киеме. *Галимҗан абыйлардан кайтканнан бирле, кайда бичәүкә я чабата киндерәсе күрсәм, шуны аркылы-торкылы тәнемә урыйм.* А.Хәсәнов. *Гомумән, чабатаны матур итеп үрә белү бездә кешенең тырыш һәм пөхтә булуын күрсәтүче бер сыйфат исәпләнгән.* А.Тимергалин

**2.** *с. мәгъ. күч.* Зур, калын. *Манцев аңа таба иелә төшеп, чабата иреннәрен сузып, карлыккан тавыш белән: – Болар нинди кешеләр? – дип пышылдады.* А.Толстой. *Укытучылар коллективы Петуховның кандидатурасын тәкъдим итүгә үк, иҗтимагый үзәк исеменнән трибунага чабата кашлы, куе кара чәчле, илле яшьләр тирәсендәге бер ир атылып чыкты.* В.Имамов

◊ **Чабата базары ясау** Берьюлы һәм тәртипсез рәвештә күп кеше сөйләү (сөйләшү); юк-бар турында сөйләшеп көн уздыру. **Чабата кайтару** 1) Юкә тасмаларны киндерәгә урап, берберсе аша үткәреп үрә башлау. *Ә мин җырлый-җырлый чабата кайтарам.* Т.Гыйззәт. *Ничек чыксын, чабата кайтарып утыра ич, тезенә җүкәләр бәйләгән ие.* Г.Шәрәфи; 2) Уңай фикерне кире мәгънәгә бору, хәйләләү, каршы сөйләү; булмастайны бар дип күрсәтү. *Чабата кайтарма, кушканны үтә!* З.Мәхмүди. *Арбага бишенче тәгәрмәч кую, самолётка өченче канат тагып*

*утыру гына ич болар?! Булмаганга чабата кайтару!..* А.Гыйләҗев. *Мәтәштерәсең, имеш! Без эш эшлибез, ә сез чабата кайтарып, акча алып ятасыз!* Х.Камалов. **Чабата туздырып йөрү** Файдасызга, бушка йөрү. *Ә нигә вакыт уздырып, чабата туздырып, мәшәкатьләнеп торырга?* В.Нуруллин. *– Гомер уздырып, чабата туздырып ник укып йөрисең инде син? – дип, һич тә көтелмәгән яктан сүз башлады Хәби.* В.Имамов. **Чабатаны түргә элү** Үз мәнфәгатьләреннән чыгып, үзенә ничек кирәк шулай эш итү. *Алардан да бераз сабак алсын. Бәлки әле, байгуралары да Түргә элми башлар чабатасын.* Г.Морат. *Үзебезнең фәлән абзый малае, фәлән апа кызы булуыбызны «онытып», кем әйтмешли, чабатабызны түргә элмәдекме?* М.Вәлиев. *Бер-беребезне аңлап, ярдәмләшеп эшләдек, һәрхәлдә, түрә булып утыргач та чабатасын түргә элә торган гадәте юк кебек иде аның.* Р.Мөхәммәдиев. **Чабата хәтле** Бик зур. *Әсир Мөхәммәт, үзе генә җиңә алмавын аңлап, челтәрле тимер капканы чабата хәтле йозагы белән бикләп, үзе казыйга китә.* К.Тинчурин. *Симертсен, иртәгә мәктәпкә килгәч, барыбер үзенең чабата хәтле авызын ачып иснәп утырачак ул.* З.Хөснияр

**ЧАБАТА́ БАСЫМЫ** *и. иск.* Чабата эзе кадәр булган озынлык үлчәү берәмлеге. *Чабата басымы да чабата эзе хәтле араны белдергән.* А.Тимергалин

**ЧАБАТА́ БАШМАК** *и. иск.* Баусыз, тирән эчле чабата. *Йорт эшләре өчен тиз генә салып, тиз генә киеп була торган чабата башмак (киндерәсез, тирән), ката дип аталган.* А.Тимергалин. *Башына каешланган кара түбәтәй, өстенә киндер күлмәк белән алача ыштан кигән, йон оекбаш белән чабата башмакны аягына элгән Рамазан карт кунакны каршы алырга үзе чыкты ---.* Г.Ахунов

**ЧАБАТА́ БҮРӘНӘ** *и. диал.* Матча өсте бүрәнәсе

**ЧАБАТА́ КАЛАГЫ** *и. иск.* Киндерәне, шуның аша чыгарып, атландырып бәйләү өчен тишекләр

**ЧАБАТА́ КӘМИТЕ** *и. иск.* Балаган. *Электә мондый чабата кәмитләрен Казандагы Черек күл янында урнашкан балаганда уйнаганнар.* А.Тимергалин

**ЧАБАТА́ КҮЗЕ** *и. к.* **чабата калагы**. *Шактый ук каршылар без. Хис – йөрәк шөшле булса, Чабата күзе саен – без!* Н.Гамбәр

**ЧАБАТАЛЫ** *с.* **1.** 1) Чабата кигән, чабатасы булган. *Юлымда берничә чабаталы адәм очрады; алар агачка сөяло төшеп музыка тыңлыйлар, күзләре тәмле нигъмәтләр белән тулган буфетка, андагы симез җилкәләргә кадалган иде.* Г.Ибраһимов. *Шул сүзләр белән озын буйлы малай иске чабаталы аягы белән Санияне күкрәгеннән этеп җибәрде.* А.Фәләх

2) *күч.* Ярлы, фәкыйрь. *Зал тагы тавыш, шау-шу белән, сызгыру вә аяк тибү белән, «Долой, кирәкми, бетмәс монда чабаталы социалистлар!» дигән кычкырынулар белән тулды.* Г.Ибраһимов. *Без, чабаталы авыл малайлары, бермәлгә аптырашта калдык.* А.Гыйләҗев

3) *тар.* Бөлгән, җирсез калган (морза тур.). *Ул бөлгенлеккә төшкән, ягъни чабаталы морза нәселеннән булган, дигән мәгълүматлар да бар, бик мөмкин, аның гаҗәп укымышлы булуы шуңа ишарәли ---.* В.Имамов. *Әнә аларның нәселе, әтисе әйтүенчә, чабаталы морзаларга барып тоташа.* Д.Булатова

**2.** *и. мәгъ. күч. сөйл.* Революциягә кадәр: хәрби хезмәттән азат ителгән кеше. *Революциягә кадәр, гаскәри хезмәттән азат ителеп, берәр ай сугыш уеннары уйнап өйрәнеп кенә йөргән кешеләрне дә (кызыл билетка калганнарны) чабаталылар дип атаганнар икән.* А.Тимергалин

**ЧАБАТАЛЫК** *с.* **1.** Чабатага дип билгеләнгән; чабатага яраклы. *Урманнарда Мин эзләгән зелпе тамыры, Мин кисәсе чабаталык юкә, – Азга түгел, Гомерлеккә...* М.Шабаев. *Әүвәлдән килгән хәл бит инде: чабаталык курыс төшергән өчен дә, кешенең аяккулларын сындырып кайтарырлар иде ул урманнан.* М.Хәсәнов

**2.** *и. мәгъ.* 1) Чабата ясау өчен материал. *Тауларымда йөрмәгез, Урманыма кермәгез, Чабаталык кисмәгез, Кизләүдән су эчмәгез!* Ш.Галиев

2) Чабата алырлык күләмдәге. *Сәләтсез Гайнетдин кебекләр генә, чабаталык та акчалары булмаганнан, яланаяк.* Ватаным Татарстан

**ЧАБАТА-ОЕК** *җый. и.* Аяк-чу, оекчабата. *Аягы да ялангач булып, чабатаоек киеп ул, әлбәттә, мәшәкатьләнмиһәм башка нәрсә дә кими иде.* Г.Ибраһимов. *[Ахунҗан:] Аннан соң партия коммунистларга ертык киемнән, чабата-оектан йөрергә дә кушмый бит.* Т.Гыйззәт

**ЧАБАТА́ ТАРАКАНЫ** *и. диал.* Таракансыманнар отрядыннан ялтырап торган кара төстәге синантроп таракан; кара таракан; *русчасы:* **чёрный таракан**. *Мич асты бездә чабата тараканы дип йөртелә торган кара таракан белән тулы була иде.* Татарстан яшьләре

**ЧАБАТА́-ЧАБАТА** *с. сөйл.* Зур, эре (бер иш әйберләр тур). *Чабата-чабата кара шадралар арасына сибелгән Киек Каз Юлы төсле зәңгәр дары бөртекләрен күргәч, чулак Гыйбадулла --- кычкырып җибәрде.* А.Гыйләҗев

**ЧАБАТАЧЫ** *и.* Чабата ясаучы; чабата сатучы. *– Ә син – шөшлесез чабатачы! – диде.* А.Гыйләҗев. *Алар чабатачы аягындагы чабаталарга карап торганнар да, чабата үрергә өйрәнмәкче булып, шундук теге кешене уратып алганнар.* Г.Гыйльманов

**ЧАБА́ ЧҮБЕ** *и. диал.* Песи тарысы, кырмыза; *русчасы:* **амарант**

**ЧАБУ** I *ф.* 1) Үлән яки игенне чалгы, чапкыч белән кисү. *Үзенә тагылган машинасы-чалгысы белән бер-ике көндә бөтен болынны чабып та китә.* А.Алиш. *Хәзер печән бик кадерле, берәрсе, чабып, култык астына кыстырып китсә?* А.Гыйләҗев

2) Балта, пычак кебек нәрсәләр белән сугып кисү, өзеп алу. *Соңыннан Казанда аның падишаһ исеменнән фәрманнар язган кулын чабып өзәләр.* В.Имамов. *Юныш балтасы белән чабып алынган өр-яңа йомычка!* А.Гыйләҗев

3) Чапкыч корал белән вак кисәкләргә бүлү, бөтенне ваклап бетерү. *Иң яхшысы – вак кына турап яки тагаракта чабып салу.* Казан утлары

4) Балта, лом белән нәрсәне дә булса вату, вак кисәкләргә таркату. *Берничә йорт узгач, тротуарда боз чабып торган бер кешене күрде. Кыш көне ир-атлар белән, бәке чабып, коенырга йөргәнен белә́м, морж дип йөртәләр хәзер аларны.* А.Гыйләҗев // Руда, күмер, таш казу, чыгару. *Ул шул гомеренең күп өлешен Урал шахталарында күмер чабып үткәрде.* Г.Гобәй. *Бер зур гына таш өстенә утырган да, таш чабып хәлсезләнгән, суелып, канап беткән учлары белән йөзен каплап, үксеп елап җибәргән...* Г.Гыйльманов

5) Агачка балта белән сугып, бәреп, төшеп китмәслек итеп керту. *Әхәт абый, кулындагы балтасын бүкәнгә чабып, маңгайларын сөртеп алды.* Г.Бәширов. *Балтамны бүрәнәгә чабып куйдым да, нинди ниятләр белән килде икән инде бу, нәрсә әйтмәк була икән, дип көтә башладым.* В.Нуруллин // Балта белән

эз салу. *Бикәченә бүләк өчен акча кирәк булганда, Шибай саранланып, җитәрлек бирми башласа, өсәктән урлап иген сатты, Караюргага, яшь кәләшкә барачак пәнҗешәмбеләрне, алдан бармак белән исәпләп, келәт бүрәнәсенә балта белән чабып билгели торды.* Г.Ибраһимов

6) Салкын корал белән кисеп җәрәхәтләү яки үтерү. *Иң авыры – чабып барган ат өстеннән, фехтование дип аталган ысул белән кылыч селтәп чабарга өйрәнү иде.* З.Зәйнуллин. *Кайбер кешеләрне атып яисә кылыч белән чабып үтергәннәр.* З.Мурсиев

7) *күч. иск.* Сугышу, сугыш алып бару; көрәшү. *Яу чабу*

◊ **Чапмаган да юнмаган** 1) Эре сөякле, гәүдәле кеше; 2) Тупас итеп, аннан-моннан эшләнгән әйбер. **Чапмаган, юнмаган** *к.* **чапмаган да юнмаган**. *Миңа сине – чәчен дә тарый, оегын да күтәреп кия белмәгән, чапмаган, юнмаган авыл бичәсен, эткәләп-төрткәләп, ничәмә ел шундый зур урында, йомшак кәнәфидә утырткангa рәхмәтең шулмы?* Г.Мирһади

**Чаба башлау** Чабарга тотыну. *Егетләр яңадан печән чаба башлыйлар.* А.Алиш. *Чаба башлаганчы, күрше белән ике арага ызан сызарга кирәк икән әле.* Г.Бәширов

**Чаба килү** Әлегә кадәр чабу

**Чаба төшү** Яхшырак чабу. *– Хаҗисолтан абзый, пакусыңда печәннәрең кире торып баса бит, чаба төш, – ди икән.* Мәдәни җомга

**Чабып алу** Тиз арада, көтмәгәндә чабу. *--- бул сабыр – кылычы белән тилебаш башыңны чабып алыр.* Р.Харис

**Чабып ату** *к.* **чабып алу**. *Каратай чамалап, үлчәп бетермәгән икән, Чыңгызхан бер мизгел эчендә тәнсакчының башын чабып атты.* В.Имамов

**Чабып бетерү** Тулысынча чабу, кирәкле кадәр чабу. *Бездә болын күп булганлыктан, колхоз гына аларны чабып бетерә алмый.* Г.Мөхәммәтшин

**Чабып йөрү** Чабу белән мәшгуль булу. *Әйе, йорт салу кайгысы юк иде миндә, туган, йорты кадалып китсен иде, тик мин печән чабып йөргән көннәрдә, Сәкинә Чиләбегә китеп барган булып чыкты.* В.Нуруллин

**Чабып килү** *к.* **чаба килү**

**Чабып кую** Алдан чабу; тиз арада чабу. *Имеш, күрше малайлары Мәүлетҗан белән Тукран, Генрих кушаматлы Насих үзләренекен чабып та куйганнар.* В.Нуруллин

**Чабып ташлау** Бик тиз арада, мизгел эчендә чабу; тулысынча чабу. *Бу арада хатыннар тары урды, борчак йолыкты, кибән куюдан бушаган бер яңгырлы көндә Алтынбай, үзе барып, карабодайны чабып ташлады.* Г.Ибраһимов. *Менә чабып ташланган алан уртасында алар икәүдән-икәү генә калдылар ---.* Г.Гыйльманов

**Чабып тору** Даими, әледән-әле чабу, әле, хәзер чабу. *Берничә йорт узгач, тротуарда боз чабып торган бер кешене күрде.* М.Галәү. *Аптырама, пристендә машина бетмәгән, тыз-быз чабып кына торалар.* Т.Миңнуллин

**Чабып чыгу** Барысын да, тулысынча чабу. *Ләкин тел дә, кул да үләнен чабып чыккан ялан түгел лә ул.* В.Имамов

**Чабып яту** *сөйл. к.* **чабып тору**. *Хәзер сөйләшеп карар идем дә – соң инде: мин болында печән чабып яткан вакытта, малайны иртәп, читкә – Чиләбегә чыгып киткән.* В.Нуруллин. *Шулай Келәвеш урманы аланында печән чабып яткан мулла абзыйларына авылдашлары үтеп барышлый әйтеп куймасынмы ---.* А.Хәлим

**ЧАБУ** II *ф.* 1) Бик тиз йөгерү (кеше яки хайваннар тур.). *Төлке барысыннан да соң юлга чыкса да, куян янында шактый тукталып торса да, иң туры юллар табып, бар көченә чабып, карт имән янына иң алдан барып җитә.* А.Алиш

2) Атта, автомобиль, мотоцикл кебек транспортта тиз хәрәкәт итү. *Азымбай карт бу эш өчен, җәйләүдән җәйләүгә чабып, күп ат тирләтте.* Г.Ибраһимов

3) Чабышларда, бәйгедә катнашу. *Чабачак атлар халык диңгезе буеннан йөрәкләренә чыдаша алмагандай йөриләр.* Г.Ибраһимов

4) Бик тиз хәрәкәт итү (транспорт тур.). *Поезд бар көченә чаба, безне көлдерерлек дәрәҗәдә бик нык чайкый.* А.Алиш. *Таишев рульгә утыра, фараларны кабызып, куянны тагын куа китәләр болар, машина чаба, куян чаба, мылтык ата, куян һаман чаба.* Р.Батулла

5) *сөйл.* Берәр эшне булдыру артыннан йөрү. *Мал артыннан чабып йөрдем гомер буе, Итәрмен, дип, ахыр бер көн бәхет туе ---.* Г.Камал. *Нинди кыска бу кеше гомере! Анысын да байлык, дан-шөһрәт, карьера артыннан чабып үткәрәбез.* З.Мәхмүди

6) *сөйл.* Бик еш бару. *Тәнәфес саен чабып керә, Таняны чакырып ала...* А.Гыйләҗев

7) *сөйл.* Хатынга яки иргә хыянәт итү; өстерәлү; хатынны яки ирне еш алыштыру. *Әйтүләренә караганда, Мансур нинди дер бүтән кыз артыннан чаба, имеш.* Г.Әпсәләмов. *Идрис сыман, түшәк бүлешеп, хатыннан хатынга чапмаган.* Н.Гыйматдинова

8) *сөйл.* Өстән-өстән яки ашык-пошык карау. *Күзләре хәреф өстеннән чаба*

9) *күч.* Ашыгу, даими тиз хәрәкәттә булу. *Директорның йөгерек карашлары Иңләп чаба совхоз яланын.* М.Җәлил. *Уйласаң, гел чабып, гел ашыгып үтә икән гомер.* А.Гыйләҗев

**Чаба башлау** Чабарга тотыну. *Таня әле бюро утырышына кала, әле райкомга чаба башлады.* Г.Әпсәләмов. *Сорап кала алмавына әрнегән малай кичәге абый киткән якка карап чаба башлады.* А.Гыйләҗев

**Чаба килү** Шушы вакытка кадәр чабу. *Әмма ул тиешле урыннарга чаба килде*

**Чабып алу** Бераз чабу. *Көлдереп тә алалар, Аяк чалып алалар, Атта чабып алалар...* Р.Миңнуллин

**Чабып йөрү** Билгеле бер вакытта чабу. *Кәрванның бер очыннан икенче очына чабып та йөрмәдем.* А.Гыйләҗев

**Чабып китү** Кинәт чаба башлау. *Без аны момент дәвалар идек, теркелдәп чабып китүен сизми дә калыр иде...* А.Гыйләҗев. *Дүртпочмаклап бәйләнгән иске чаршауны сүтеп җибәрүгә, Зифа шатлыгыннан бүлмә буйлап колын сыман кушаяклап чабып китә язды.* В.Имамов

**Чабып тору** Даими, әледән-әле чабу; әле, хәзер чабу. *Автобуслар, троллейбуслар, Таксилар чабып тора. Җәяүлеләр тротуардан Туктаусыз агып тора.* Ф.Яруллин

**ЧАБУ** III *ф.* 1) Биткә, яңакка каты итеп сугу. *Алай дип кимсеткәнче, яңагыма чапса, ичмаса, җиңел булыр иде...* В.Нуруллин. *Ни эшләсәң, шуның әҗерен аласың: черки үтерсәң – битеңә чабасың шул ул.* М.Әмирханов

2) Мунчада себерке яки хуш исле үләннәр белән тәнгә еш-еш сугу. *Безгә шундый рәхәт, җанга шундый тыныч, яхшы каен себеркесе белән чабып, апак күбекле кытыршы мунчалалар белән ышкып юылган тән ял итә – җылыйсы да, җырлыйсы да килә.* З.Зәйнуллин. *--- Ксюшаны миллек сулары белән, миллек белән чабып булса да дәвалап карыйм, дигәннәре – бер дә ялган да, хыяланып әйтүе дә түгел иде.* Ялкын

**Чабып алу** Тиз генә чабу. *Яңагына ялт итеп чабып та ала.* А.Гадел

**Чабып җибәрү** Көтмәгәндә чабу. *Ул бер якка шуып төшкән эшләпәсен рәтләштерде дә, ачуланган булып, искәрмәстән Бәхтинең чигәсенә чабып җибәрде.* Н.Фәттах. *Альфредның тыны кысылды, Руфинәнең яңагына чабып җибәрәсе килде, ләкин кулын күтәрерлек хәле калмаган иде.* Ф.Садриев

**ЧАБУ** IV *и.* 1) Халат кебек алдан ачылмалы киемнең итәге, уң һәм сул ачылмалары; *русчасы:* **фалды**. *Һәм Мансур, бүтән бер сүз әйтмичә, халат чабуларын җилфердәтеп, өскә – операционныйга йөгереп менеп китте.* Г.Әпсәләмов. *Каршы яктан искән җил аларның бишмәт чабуларыннан сөйрәп, авылга таба тарткалады, итек куныччларына, куеннарына учы-учы белән ярма кар тутырды.* А.Гыйләҗев

2) Кием итәгенең түбәнге өлеше, чите. *Бу ике ел эчендә Газинур, үзенең полкташ иптәшләре белән бергә, автоматын күкрәгенә асып, солдат бүреген егетләрчә кыңгыр салып, шинель чабуларын бил каешына кыстырып, очсыз-кырыйсыз фронт юлларыннан күпме атлады!* Г.Әпсәләмов. *Егете чалбар чабуына буталып йөрүче бер баламут булса икән.* А.Хәсәнов

◊ **Чабуга таккан шикелле** Бер адым да калмыйча, һәрвакыт янәшәдә. *Ә малай әнисенә караганда да көнчелрәк: әтием дә әтием дип кенә тора, чабуга таккан шикелле ияреп йөри иде.* В.Нуруллин. **Чабудан тарту** Берәр эшне эшләргә ирек бирмәү, комачаулау; үз-үзен белдереп, күрсәтеп тору. *Нихәтле ачылып китәргә тырышсаң да, ахыргача ачылып булмый, рәсмилек чабудан тарта.* Г.Әпсәләмов. *Үзебезне бераз мактап алгач, тагын да борчулы хәлләребез чабудан тарта.* Б.Рәхимова. **Чабудан тоту** 1) *к.* **чабудан тарту**. *Кыза башласаң – суытырбыз, ялгышсаң – чабуыңнан тартырбыз.* В.Нуруллин. *Ул шәһәргә килеп урнаша алмый, чөнки ярлылык чабудан тота.* Мәдәни җомга; 2) Авыр хәләткә, соңгы чиккә җиткерү. *Хәтереңдәме, Усман, --- үлем чабуыбыздан тоткан чаклар, җирдә шуышып барган вакытлар.* Ә.Ерикәй. **Чабу(лар)ны җыеп йөрү** Бик сак эш итү, сизгерлек, уяулык күрсәтү. *Рәис Кыямовичның абруе югары, киләчәккә өметләре зур чак, үзен бик саклый, элеккеге дусларын да, аз гына тайпылсалар, чабуларын җыеп йөрмәсәләр, кызганып-нитеп тормый ---.* Т.Галиуллин

**ЧАБУЛА́У** *ф.* Ашыгу, тиз-тиз йөрү, тыз-быз килү. *Цех начальнигы Хөсни Дәминович кабинетына керде дә көне буе чабулап кургаштай авырайган йомры гәүдәсе белән йомшак креслога чумды.* Н.Хәсәнов. *Арбаның әле бер, әле икенче ягына чыга-чыга чабулап чапкан колыннан күзләрен аера алмый, Булат та рәхәт чигә.* Р.Мулланурова

**Чабулап алу** Бераз чабулау. *Үзенең тиктормаслыгы, җитезлеге белән кыска гына вакыт эчендә нинди генә кыяфәтләргә кереп бетми: дугаланып килгән бөкресе белән сикереп тә, мәтәлчек атып та, дүртаяклап чабулап та ала.* К.Җәмит

**Чабулап китү** Кинәт чабулау. *– Юк бүрәнә, моннан соң ымсынып та йөрмә, – дип, ярга килеп төртелгән сал буйлап, як-якка чайкала-чайкала чабулап китте.* Ф.Сафин. *Комбайн тагын да чабулап китте.* Р.Нуруллин

**Чабулап тору** Даими, әледән-әле чабулау; әле, хәзер чабулау. *Тик шунысы: кеше анда, базардагы кебек, санаусыз арлы-бирле чабулап тора.* К.Җәмит

**Чабулый башлау** Чабуларга тотыну. *Өшәнгән, өреккән, тышау-йөгәннәрен өзгән аргамаклар бөтен лагерь буйлап чабулый башлады ---.* В.Имамов. *Иреккә чыгу шатлыгыннан бозау, кош-кортларның котын алып, чабулый башлады.* Р.Мөхәммәдиев

**ЧАБУЛЫК** I *и.* **1.** Печән чабып алырга дип билгеләнгән урын; чабынлык. *Чабулыкларны карау*

**2.** *с. мәгъ.* Печән чабу өчен билгеләнгән. *Юкә орлыгы, зелпе тамыры, имән чикләвеге җыеп тапшырган кешеләргә урманчылыктан чабулык җир дә, утынлык агач та биргәлиләр.* В.Нуруллин. *Элек биредә Идел буйлап уннарча чакрымнарга чабулык болыннар сузылган, язгы ташу вакытында ярларыннан чыккан Идел суы күз күреме еракларга җәелгән.* Казан утлары

**ЧАБУЛЫК** II *с.* Чабу өчен билгеләнгән, шуңа җитәрлек. *Чабулык тукыма*

**ЧАБЫГУ** *ф. диал.* Бер вакыйга турында сүз, хәбәр таралу. *Яңалык тиз чабыкты*

**Чабыгып китү** Кинәт чабыгу. *Бу гашыйклык бәетләре Чабыгып китте һәр төшкә.* Г.Кандалый

**ЧАБЫН** *и. сөйл.* Чабынлык. *Төнбоек та ачкан инде киң кочагын, Тәмле исләр чәчкән инде киң бу чабын, Тәбрик итә берсен-берсе бар да алар, Алкышлыйлар Зур Тәңренең изге таңын.* Ф.Бурнаш

**ЧАБЫНДЫРУ** *ф.* 1) Мунчада себерке белән чабу. *Кунакларны җитәкләп ләүкәгә менгезделәр дә, киң һәм иркен ләүкәнең ике башына икесен яткызып, алдан пешекләп куелган каен себеркесенең яфраклары коелып беткәнче чабындырдылар.* М.Галәү. *Ә күрше Шакир малаен да бик шәпләп мунча кертергә кирәк булыр: иң эссесендә чабындырырга...* Н.Акмал

2) *күч.* Орышу, шелтәләү, сүгү. *Җыелышта тагын чабындырдылар яшь җитәкчене*

**Чабындыра башлау** Чабындырырга тотыну. *– Кем карар соң син бичараны, мин карамасам? – дип такмаклыйтакмаклый чабындыра башлады.* А.Гыйләҗев

**Чабындыра бирү** Бернигә карамый чабындыру

**Чабындыра төшү** Берникадәр чабындыру

**Чабындырып алу** Бераз чабындыру

**Чабындырып бетерү** Бик нык чабындыру

**Чабындырып тору** Даими, әледән-әле чабындыру; әле, хәзер чабындыру

**ЧАБЫНЛЫК** *и.* **1.** Печән чабу өчен билгеләнгән урын, болын; чабын, чабулык. *Хәер, авыл китеп беткәч, күпләргә бу чабынлык кирәкми дә, анда хәзер Сәкинәдән башка йөрүче дә юк.* Ә.Эминев. *Бәй, үзләренең чабынлыгына борыла торган сукмак түгелме соң бу?* Т.Гарипова

**2.** *с. мәгъ.* Печән чабу өчен билгеләнгән. *Чабынлык җирдә Миңсылу гына утырып калды.* М.Галәү

**ЧАБЫНУ** *ф. кайт. юн.* Мунчада үз тәнеңне үзең себерке белән чапкалау. *Байбикә исә, әле генә чабынып ләүкәдән төшкән кеше сыман хәлсезләнеп, баш астына йомшак беләкләрен салып, чалкан ятты, урынны да мактап куйды.* М.Хәсәнов. *Елга бер түгел, атнага бер чабынмасаң да чир баса лабаса.* Р.Батулла

**Чабына башлау** Чабынырга тотыну. *Тагын ләүкәгә менеп ята, бераздан аһылдый-ухылдый чабына башлый.* Р.Батулла. *Рәшит аның саен кыздыра, ә мин чабына башлыйм.* З.Зәйнуллин

**Чабына тору** Әлегә чабыну. *Кыскасы, мунчага үзем генә барып, парланып, чабына торырга булдым, җиңгәччәң соңрак, юк акылын башкалар белән уртаклашкач килергә карар кылды.* И.Кашфразыев

**Чабына төшү** Яхшылабрак чабыну

**Чабынып алу** Бераз гына чабыну. *Бүген ял ит, мунча ягып чабынып ал, ә иртә таң белән юлга чыгарсыз.* И.Хуҗин. *Монысы, күрәсең, мунча кереп, чабынып алган – йөзе, муены түтәлдә пешкән помидор кебек алланып тора...* Т.Гарипова

**Чабынып бетерү** Чабынуны төгәлләү. *Кунакны кимсетеп булмый бит инде: чабынып бетергәч, ләүкәгә Зәки абыйны сузып яткырган да, и төя, ди, моны, и төя, ди, пәһлеван гәүдәле кунагы түшәм белән ләүкә арасында тегенең себеркесенә ябышып, кульяулык кебек ияреп йөри икән.* Ф.Яхин

**Чабынып җибәрү** Бераз чабыну. *Бераз парланып алгач, хуш исле мунча себеркесе белән дә чабынып җибәрсәң, ару-талчыгуларың су белән юып алгандай юкка чыга, кәефләр күтәрелә, кан әйләнеше яхшыра, мускуллар һәм буыннар йомшарып киткәндәй була.* Хезмәт даны

**Чабынып калу** Чабынырга өлгерү. *Әйдәгез, егетләр, полковник үзе кергәнче чабынып калыйк.* З.Зәйнуллин

**Чабынып тору** Даими, еш чабыну; әле, хәзер чабыну

**Чабынып яту** *сөйл. к.* **чабынып тору**. *Сарниклар чабынып ятканда, мунча ишегенә безнең капканың бер канатын китереп сөягәннәр дә, алар эчтә бикләнеп калганнар икән.* Г.Бәширов

**ЧАБЫР** *и. рус бот.* Иренчәчәклеләр семьялыгыннан яфраклары эфир майларына бай булган куак яки ярымкуак үсемлек; *русчасы:* **чабрец**. *Хәзер инде ул әрем, чабыр исләреннән исереп, тау җилләренә йөзен куеп, йолдызлы күккә карап хыялланып кына калмый, Аксу-Җабагалы тыюлыгының үсемлекләр дөньясына багышлап мәкалә арты мәкалә яза.* Т.Әйди. *Саф һавага ул арада чабыр исләре таралып өлгерә.* Казан утлары

**ЧАБЫ́Р БӘЙРӘМЕ** *и. этн.* Бөтен халык җыелып, 1–3 июль тирәләрендә үткәрелә торган һәм сыра эчү белән бәйле бәйрәм. *Бүгенге тормыш үзе ни тора?! Андагы сабан туйлары, чабыр бәйрәмнәре...* Ә.Баян

**ЧАБЫР ҖЫЕНЫ** *и. к.* **чабыр бәйрәме**. *Әтрәч халкы күрше авыллар белән бергә чабыр җыенын бәйрәм иткән.* Ф.Гарипова

**ЧАБЫРТКЫ** *и.* Салкын тигәннән, авырудан әгъзаларга чыга торган сулы бетчә, сыткы; *русчасы:* **огневица**. *Инәсенең күз яшен күрүгә, гүя аның тәненә чабырткы чабыртып чыга һәм тәнен меңләгән энәләр белән чәнчи башлый.* А.Хәлим

**ЧАБЫРТМА** *и. к.* **чабырткы**. *Иренгә чабыртма чыгу*

**ЧАБЫРТУ** *ф. к.* **чабыру**. *Аннан инде, иренең чабыртса да, шайтан үпкән, диярләр.* Р.Кәрами. *Болардан тыш, еш суык тию, ОРЗ, ангина, гайморит, полиплар да була, авыз тирәләре еш чабырта, герпес чыгып интектерә.* Безнең гәҗит

**ЧАБЫРУ** *ф.* Чабырткы чыгу, чабырткы белән каплану. *[Әбүзәрнең] Иреннәре чабырган, температурасы югары.* А.Тимергалин. --- *иреннәре чабырганчы кәҗә сакалы, кузгалак, юа, какы ашап, чишмәдән ярыша-ярыша су ташып, кишер-чөгендер утап, эшләп-ныгып авылда үсteләр алар.* Р.Мулланурова

**Чабыра башлау** Чабырырга тотыну. *Менә шуны салкыннар башланганчы эшләп куеп, ирен чабыра башлауга ук сөртә башласаң, тизрәк терeләсең.* Ватаным Татарстан. *Ирен чабыра башлауга ук, сарымсакны изеп согын чыгаралар һәм сөртәләр.* Мәдәни җомга

**Чабыра төшү** Бераз чабыру

**Чабырып бетү** Бик нык чабыру

**ЧАБЫР ҮЛӘНЕ** *и. к.* **чабыр**. *Кичкә рәйханнан һәм кайсы ягы беләндер бөтнекне хәтерләткән чабыр үләненнән гаҗәеп хуш исләр тарала.* Р.Мирхәйдәров

**ЧАБЫ́Р-ЧАБЫР** *иярт.* Пычрактан, юеш кардан барганда чыккан тавышларны белдерә

**ЧАБЫ́Р-ЧАБЫР ИТҮ** *ф.* Пычрактан, юеш кардан барганда чабыр-чабыр иткән тавышлар чыгу; чапырдау. *Караңгы күк йөзеннән вак-вак күбәләкләр шикелле карлар очып кешеләр өстенә сырыша, киемнәр чылана, аяк асты чабыр-чабыр итә.* Ш.Камал

**ЧАБЫ́Р-ЧАБЫР КИЛҮ** *ф. к.* **чабы́р-чабыр итү**

**ЧАБЫШ** *и.* **1.** 1) Атлар узышы; бәйге. *Безнең Арча ягында Сабан туенның каймагы, иң шау-шулы, иң күңелле өлеше, көрәш белән чабышларның да иң кәттәсе икенче көнне башлана.* Г.Бәширов. *Татар ат чабышларын яраткан, мондый ярышлар Сабантуйны бизәп торганнар.* А.Тимергалин

2) Гомумән ярыш. *Һоп, егетләр, башка илһам килде, Үзе көнчел күңел, үзе дәртле – Бу чабышта узып китсәк иде Гомәр Хәйям белән Дәрдемәндне!* Г.Афзал

3) Чабу, чабу күренеше. *Ярык Таба яланын мәхшәр көнендәге сыман тавыш күмде, ыгы-зыгыдан, атлар чабышыннан бар иңкүлек дер-дер калтыранды.* В.Имамов. *Ямьле мәҗлесләргә чабыш Әшнәләр, дуслар белән ---.* Г.Афзал

**2.** *с. мәгъ.* Бәйгедә катнашу өчен махсус үстерелә торган. *Болайга киткәч, ни шайтаныма дип чабыш атлар үстерергә?* Г.Бәширов. *Икмәк, малтуар белән сату иткән, чабыш атлар тоткан, кымыз бияләре асраган.* Г.Госман

**ЧАБЫ́Ш АТЫ** *и. к.* **чабышкы**. *Яшь айгырлар, байталлар, чабыш атлары, аран тәрәзәләреннән башларын сузып, кырлардан, болыннардан агылган бераз дымлы, бераз җылымсарак яз һавасын озак-озак исниләр.* Г.Бәширов. *Сабан туе җиткәч, чабыш атын аранда кем тота ала?* А.Гыйләҗев

**ЧАБЫШКЫ** *и.* **1.** Чабышларда катнаша торган, чабыш өчен махсус үстерелгән ат. *Өлкәнрәкләр, юл сабып: – Юртакларга урын бирегез! Сабан туе чабышкылары килә! – дип кычкырып, сызгырып, тел шартлатып, көлешеп безне озатты.* А.Гыйләҗев. *Ата-бабадан калган бу бәйгә атна буена дәвам итә, анда барча җәйләүләрдән килгән чабышкылар катнаша.* М.Әмирханов

**2.** *с. мәгъ.* Ат чабышында катнашу өчен махсус үстерелә, асрала торган. *Мукшы бае ата-бабадан дәүләтле килеп, бөтен мукшылыкка каршы уларак, искедән бирле өзлексез бер чабышкы ат асрыйлар, һәм бу атның һәркайчан бөтен тирә-як чабышкыларыны узарлык булуыны алга тоталар иде.* Г.Ибраһимов. *Күрше урман шүрәлеләре чабышкы айгырыбызны урлап киттеләр дип, милициягә барып бирәү дә чакмый, жалу бирми.* А.Хәсәнов

**ЧАБЫШКЫЛЫК** *и.* Чабышкы булу, чабышкы сыйфаты. *Ул көз алган таен кыш буена карый, тәрбияли, кешеләргә аның чабышкылыгы хакында галәмәтләр сөйли.* Г.Ибраһимов

**ЧАБЫШТЫРУ** *ф.* Атларны узыштыру, ярыш ясау. *Әхмәтләр авылында сабан туйлар булмый, махсус ат чабыштырмыйлар.* Г.Әпсәләмов. *Жылкыларны, яу байталларын һәр көнне чабыштырырга, аякландырырга кирәк!* Р.Батулла

**Чабыштыра башлау** Чабыштырырга тотыну

**Чабыштыра килү** Күптәннән бирле чабыштыру

**Чабыштырып тору** Әле, хәзер чабыштыру

**ЧАБЫШУ** *ф.* 1) *урт юн. к.* **чабу** II. *Җил чак кына тибрәтте исә, шау чәчәккә күмелгән алан буйлатып төрле төстәге дулкыннар чабышып үтә, алар өстендә уенчык җилкән шикелле күбәләкләр чайкала иде.* А.Тимергалин

2) Әле бер, әле икенче якка йөгерү, тиз-тиз хәрәкәтләнү. *Тышта, табаннарына ут капкан шикелле, йөзбашлар белән ясавыллар чабыша, хәтта меңбашлар да ни кылырга белми изалана ---.* В.Имамов. *Озак вакыт үтмәде, төркем-төркем булып чабышып кергән дошман гаскәре кальга эчен тутырды.* Р.Гали

3) Чабышта катнашу, чабышта ярышу (ат тур.). *Шәһәрнең яшәү гаме бүрекләләр ярышына корылган: җыеннары – бәйге тотып, уңыш бәйрәмнәре – сүз куешып, атлары – чабышып, машиналары узышып куандырыр.* К.Кәримов

**Чабыша башлау** Чабышырга тотыну. *Уйнарга бер сылтау эзләп кенә торган яшьләре дала туздырып чабыша башладылар.* Г.Ибраһимов. *Хатын-кызлар өстәл янына утырмаган иде, мулла сүзен тәмамлауга, кул күтәреп дога кылдылар да, аш чыгарырга кирәк дип, тыз-быз чабыша да башладылар.* А.Әхмәтгалиева

**Чабышып алу** Бераз чабышу. *Кашка бәрәннәрнең арлы-бирле чабышып алуын Сәрвия белән Галияр сөенешеп карадылар.* М.Хуҗин

**Чабышып килү** Әлегә кадәр чабышу

**Чабышып тору** Әледән-әле чабышу; әле, хәзер чабышу. *Кыскасы, шәһәрнең машиналар тыз-быз чабышып торган Тынычлык урамында вакыт саташкан.* Р.Бәшәр

**ЧАБЫШУЧЫ** *и. сөйл. к.* **чабышчы.** *Барлык чабышучыларны да узып, билгеләнгән урынга якынлаштым дигәндә генә... --- атым аша мәтәлеп, шап итеп җиргә сеңдем.* Н.Сәйяр

**ЧАБЫШЧЫ** *и. сөйл.* 1) Ат чабышында катнашучы кеше, жокей. *Чабышчы малайның аркасына танавын төртеп, мәйданның бер читендә кунак кызыдай оялчан гына торган бу кырыкмышны әллә каян күреп алды.* А.Хәсәнов. *Байрак булып күккә күтәрелгән Сабантуйның чуар сөлгесе. Ат уйнатып йөри чабышчылар, Мәзәк сөйли шаян теллесе.* Р.Вәлиев

2) Йөгерешче, йөгерү ярышында катнашучы кеше. --- *укырга дәртләнеп өлгергән егет, йөгерүдән туктала алмаган чабышчы кебек, бер урында калырга теләмәде, институтка барып керде.* Г.Ахунов. *11 май көнне уздырылачак Казан җиңел атлетика марафоны республикага чит илләрдән дә чабышчыларны җәлеп итәчәк.* Шәһри Казан

3) Чабышкы. *Турысын әйтергә кирәк, элеккеге Сабантуйларда елы-елы белән юртаклар ярышында 3–4 чабышчы гына катнашкан очраклар да була торган иде.* Әлки хәбәрләре

4) Атчабар. *Андый хәбәр килә икән, мин сиңа чабышчы җибәрермен, Батбай илхан.* М.Хәбибуллин

**ЧАБЫШЫП** *рәв.* Ашыгып; узышып; тиз-тиз. *Гомер буе чабышып план кудык, Тыннар бетеп, күзләр тонганчы.* Г.Афзал. *Алмагачларына күз явын алырлык җете кызыл тасмалар бәйләп бетереп килгәндә, Мостафаның башыннан нинди генә уйлар чабышып үтәргә өлгермәде тагын.* Ф.Сафин

**ЧАБЫ́Ш ЭТЕ** *и. зоол.* Киекләрне аулау өчен махсус өйрәтелә торган ау этләре токымнарының төркеме. *Рус чабыш этләре нәселе*

**ЧАВЫЛ** *и. диал.* Каен куаклыгы, яшь каенлык. *Сыерчык чырлый чавылда, Сайрап тора чык та чык.* З.Мурсиев

**ЧАВЫЛЛЫК** *и. диал.* Берничә чавыл, яшь, вак каенлыклар булган урын. *Без чавыллыкка җитәбез икән.* М.Хуҗин

**ЧАВЫ́ЧА** *и. ительмен зоол.* Сөләйман балыклар семьялыгыннан зур башлы, вак кара тимгелле, иң эре Тын океан сөләйман балыгы. *Чавыча һәм башка Камчатка балыклары әзерләргә Ерак Көнчыгышка вәкил очты.* А.Гыйләҗев. *Палтусны чавыча белән чагыштырып буламы соң!* А.Хәсәнов

**ЧАГА** I *и. диал. иск.* 1) Бала. --- *аларның чагалары халык җилкәсен кимерә дә хаксызга туплаган акчаларын чит ил банкларына күчерә, анда Аксарай шикелле виллалар салдыра...* А.Тимергалин

2) Хайван баласы. *Куй чагасы*

**ЧАГА** II *и. иск.* Чаккыч, чагу угы. *Бал корты чагасы*

**ЧАГАЛА́У** *ф. диал.* Балалау (җәнлекләр тур.). *Менә этләрем чагалады, балаларын җәл чыгарып ташларга, арзанга гына чыгып сатарга булдым, карагыз – барысы да машина багажнигында.* В.Ильясов

**ЧАГАН** *и. монг. диал.* **1.** Өрәңге. *Карпат итәкләре очына карасаң башың әйләнердәй пәһлеван кипарисларга, йөзьяшәр наратка, чал сакаллы картлар кыяфәтен алган карагай агачларына бик бай түгел, аның кара-вы чегән итәгедәй катлы-катлы булып тезелгән баскычларында зирек, чаган, элмә, шомырт, сәрви куаклары санап бетергесез.* В.Имамов. *Чаган – өрәңге янындагы алмагач беркайчан да мантый алмый.* А.Хәлим

**2.** *с. мәгъ.* Шул агачтан ясалган. *Ишек ачылды, зур чаган табак белән кымыз күтәреп, тукал керде.* Г.Ибраһимов

**ЧАГАНЛЫК** *и. к.* **өрәңгелек**. *Камилә платформалар читеннән үк башланып киткән чаганлык артында нindидер өй кыегын шәйләп алды.* Г.Гыйльманов

**ЧАГАРАК** *и. к.* **чаңгырак**. *Ләкин бу гына аз иде әле: өйнең түбәсе түгәрәгрәк рәвештә булсын өчен, бераз бөкрәйтеп ясалган, өч бармак калынлыгы агачларның – уыкларның югары башларын чагаракның тишекләренә тыктылар, түбән башларын кирәгәнең югары ягына беректерделәр.* Г.Ибраһимов

**ЧАГАЮ** *ф. диал.* Начараю, начар якка үзгәрү. *Кияү мулланы тәрбия кылу, кияү мулланы сыйлау аның югын ашаганга, сарысын сауганга, аның хәле чагайганнан чагайды.* Г.Исхакый

**ЧАГУ** I *ф.* 1) Чаккыч, чага кадап агулау (кайбер бөҗәкләр, чаян тур.). *Сорыкортлар үзләре бал җыймыйлар, бик юашлар, чага да белмиләр, ә бит менә кышка дигән азыкны ашап йөриләр.* А.Алиш. *Мәсәлән, мин, Әнәс Җаббаров, рәтсез һәм кирәксез мыжыкка әйләнү белән, чаян кебек үз-үземне чагып үтерәчәкмен.* Н.Гыйматдинова

2) Елан тешләү. *Шунда ызанда ятып йоклаган тырмачы малайны караелан чаккан.* А.Гыйләҗев. *Тузбаш тешләсә, агулы елан чакканнан да яман, диләр.* А.Хәсәнов

3) Кармавычларында урнашкан чаккыч күзәнәкләрдән агу чыгарып, башка җан ияләрен пешерү (медузалар тур.). *Шунда диңгез буенда медуза чагып тәне пешкән әбине күрдем.* Акчарлак

4) Чәнчү, чәнчеп авырттыру яки җәрәхәтләү (энәле яки чаккычлы үсемлекләр тур.). *Үз янында гына сыңар аякта сикергәләгән җитү кызны күргәч, Исхак тагын да түбәнгәрәк чүкте, төрле яктан ишелгән кычыткан яфраклары аны аяусыз чактылар ---.* А.Гыйләҗев. *Әрем – чүп үлән, кычыткан кулны чага, аларны йолкып ташларга кирәк ---.* А.Хәсәнов

5) Берәр нәрсә тиеп авырттыру, җәрәхәтләү. *Әллә үзен үзе белештерми*

*җиргә тәгәрәве булышты, әллә авыр яралы Нәзирнең хәлсезлеге, ашыгуы ярдәм итте – Байкучатовның күкрәгенә төзәлгән пулялар аның беләген һәм иңбашын гына чагып узды.* Т.Әйди. *Сулуы кабынды, урам ташлары ялан тәпине чагып авырттырдылар.* А.Гыйләҗев

6) *күч.* Әләкләү, кеше өстеннән гаепләп сөйләү; авыр сүз әйтү. *Дус-ишләрнең иң яманы, диләр, Астыртыны – астан чакканы.* Г.Морат

**Чага башлау** Чагарга тотыну. *Күңелләрем нечкәреп, кайгы басып, Кальбләрне кара җылан чага башлый.* З.Бәшири. *Шунда ук бөтен тәнен утлы шөпшә күче тешли, чага башлаган кебек булды.* З.Фәтхетдинов

**Чага тору** Бернигә карамый чагу; кат-кат чагу. *Югыйсә Канифә, җае чыккан саен, Римма апасына Айсинәне чага торды да торуын.* Н.Көбәш

**Чагып алу** Кинәт чагу. *– Галстугын шәһәрдә сәке астында онытып калдыргандыр әле, – дип чагып алды Өлфәт.* А.Тимергалин. *Тәкәббер ханны чагып алырга уңайлы очрак табылуга сөенде генә ---.* В.Имамов

**Чагып бетерү** Бик каты чагу, бик күп чагу. *Кортлар да чагып бетерә үзләрен.* А.Хәсәнов

**Чагып калу** Чагырга өлгерү. *Тик шуңа да карамастан, Фәнис чигенергә җыенмый, укытучысын чагып калу җаен таба.* Ш.Алпар

**Чагып кую** Көтмәгәндә чагу. *– Азым әкә, үзең яхшысың, мәгәр кайбер вакыт яман телең адәмне чагып куя, – диде.* Г.Ибраһимов. *Беркөн Вилдан үрчеткән бал корты Мостафаның шәһәрдән кайткан онытын чагып куйган.* Р.Ахунова

**Чагып тору** Даими, әледән-әле чагу; әле, хәзер чагу. *Ник дисәң, халык көнчел, бер-берсен чагып кына тора.* Н.Әхмәдиев. *Гел яманны гына тотсаң истә, Хәтер дигәне дә хәтәр ул: Йөрәгеңне көн-төн чагып торган Зәһәр елан булып ятар ул.* Л.Шагыйрьҗан

**Чагып чыгу** Барысын да чагу. *Югыйсә ул безнең барыбызны да чагып чыгар!* А.Гадел

**ЧАГУ** II *ф.* Чакмага корыч кисәге белән бәреп, очкын чыгару. *Ташны ташка чаксаң, уты беленер.* Әйтем. *Касыйм чакма чагып ут кабызды.* И.Хуҗин. *Ул челеменә озаклап кына тәмәке тутырды, чакма чага башлады, ләкин очкын гөмбәгә эләкми, ут үрләп китми иде.* Казан утлары

**Чага башлау** Чагарга тотыну. *Ул челеменә озаклап кына тәмәке тутырды, чакма чага башлады, ләкин очкын гөмбәгә эләкми, ут үрләп китми иде.* Казан утлары

**Чагып алу** Кинәт чагу

**Чагып җибәрү** Тиз генә чагу. *Тәмәкесен төреп, чакмасын чагып җибәрсә, ни күзе белән күрсен: ап-ак чапанлы карт аның чанасына утырып бара икән.* Мөслим төбәге фольклоры

**Чагып кую** Бер тапкыр чагу

**ЧАГУ** III *ф.* Яктылык, кояш нурлары, аклык һ.б.ш. күзне чагылдыру. *Шәүләләрдән башка беркем юк иде бит – Кем бүлмәмдә күзне чагып ут тергезде, Кем соң үпте кучкардагы үксез шәмне?!* Л.Зөлкарнәй. *Елтыр нурлар, кар җемелдәвенә әйләнеп, күзне чага, ап-ак очкыннарга күтәрелеп карап та булмый ---.* А.Вергазов

**ЧАГУ** IV *и.* Бик якты урын; кояш нурларының чагылдыруы. *Чагуга каршы бару*

**ЧАГУЧЫ** *и. сөйл. к.* **әләкче**. *Гөнаһысына кермим, чагучылар алар авылында ике-өч булгандыр.* Р.Батулла

**ЧАГУЧЫЛЫК** *и. сөйл.* Әләкчелек. *Әмма ләкин чагучылык армиядә юк дигән сүз түгел бу.* Казан утлары

**ЧАГЫЛ** *и. диал.* Калкулык, кояш нурлары төшә торган тау бите. *Тауларга ла мендем, шонкар чөйдем, шонкар чөйдем, Чагылларга төшкән лә шул.* Җыр

**ЧАГЫЛДЫРГЫЧ** *и. физ.* **1.** Яктылык, җылылык нурларын яки электромагнитик дулкыннарны һ.б. кайтаргыч пыяла яки металл пластина; *русчасы:* **отражатель**. *Өйалдындагы идән такталарын күтәреп карагач, тагын бер табышка ия булдылар – ике чагылдыргыч куеп эшләнгән кесә фонаре иде бу.* З.Фәтхетдинов. *Мондый фараларда үтәкүренмәле поликарбонаттан ут тараткычлар өчен эшләнгән чагылдыргычлар кулланыла.* Хезмәт даны

**2.** *с. мәгъ.* Нурларны, дулкыннарны кайтара торган. *Чагылдыргыч тасма*

**ЧАГЫЛДЫРУ** *ф.* 1) Ялтырап торган шома өслегендә кеше яки әйбернең сурәтен күрсәтү, кире кайтару. *Ай нурын чагылдырып, дулкыннар тибрәнә, алар әйтерсең җанлылар, әйтерсең аларның өстенә көмеш сибелгән.* Г.Әпсәләмов. *Сез утыз кош, һәм бу көзге сезгә утыз кошны чагылдыра, әгәр кырык, илле кош булса, алар да анда үзләрен күргән булырлар иде.* А.Тимергалин

2) Берәр күренеш яки предмет сыйфатын, үзенчәлеген икенче әйбердә яки икенче әйбер белән кабатлап күрсәтү, гәүдәләндерү. *Сүзлекнең фәнни яктан эшләнеше, әлбәттә, күпкә яхшырак, һәм ул шул чорның лексикасын тулы чагылдыра.* А.Тимергалин

3) Тормыш-яшәешне, табигатьне сәнгать чаралары белән әсәрдә, картиналарда, сәхнәдә тасвир итү. *Тарихыбыздагы әллә кайчангы чорны чагылдырган «Әүлия кабере» повестенда тарихи сүзләрдән һәм архаизмнардан иркен файдаланылган, диалекталь сүзләр дә шактый ---.* А.Әхмәдуллин. *Фән белән сәнгать чынбарлыкны үзенчәлекле алымнар һәм формалар белән чагылдыралар.* К.Гыйззәтов

4) Яктылык нурлары күзгә туры килеп, күзне вакытлыча күрмәс хәлгә китерү; чагу. *Батып бара торган кояшны да юып киткәндер шикелле: аның нурлары хәзер аеруча чиста, үткен, күзне гадәттәгегә караганда да ныграк чагылдыра иде.* В.Нуруллин. *Бәллүр бөҗраларның сихри балкышыннан агылган бу яктылык күзләрне, юк, күзләрне генә түгел, күңелне чагылдыра иде.* А.Әхмәтгалиева

5) *күч.* Рухи хәлне, уй-фикерне сүздә, йөздә яки хәрәкәттә сиздерү, белдерү. *Белорус атларга кызыксынуны бөтенләй чагылдырмаган кара күзләрен текәп, аларны берәм-берәм карый башлады.* З.Зәйнуллин

**Чагылдыра башлау** Чагылдырырга тотыну. *Мөгаен, мондый тирән газап төсмерен Мирзаһит Александр Фадеев йөзендә күргәндер дә соңыннан, ихтыярсыз, шуны үз йөзендә чагылдыра башлагандыр.* Г.Әпсәләмов

**Чагылдыра бирү** Бернигә карамый чагылдыру. *Тышта кояш җылысы, кар күзәнәкләрен чагылдыра биреп, язны ашыктыра.* Казан утлары

**Чагылдыра тору** Әлегә чагылдыру; даими чагылдыру

**Чагылдыра төшү** Тулырак, киңрәк чагылдыру

**Чагылдырып алу** Кинәт, бераз чагылдыру. *Аның җылы нурлары чагылдырып ала, тәннәрне иркәли, күкрәкләрдәге ярсуны кузгата.* Р.Мөхәммәдиев

**Чагылдырып бару** Даими, эзлекле чагылдыру. *Әнә шул кычкырып укулар, мәктәп тормышын «Коммунизмга» газетасында даими язмалары белән чагылдырып барулары балаларда*

*әдәбиятка мәхәббәт тәрбияләмәгән дип кем әйтә ала?* Г.Әдһәмова

**Чагылдырып бетерү** Тулысынча чагылдыру. *Ул хисне картиналарда гына чагылдырып бетереп булмыйдыр.* Г.Галиева. *Охшаш тәңгәллекләрнең барысын да чагылдырып бетермәдек.* Р.Әхмәтьянов

**Чагылдырып җибәрү** Кинәт, көтмәгәндә чагылдыру. *Кинәт Габитның күзен кош аягына бәйләнгән нәрсәдер чагылдырып җибәрде.* Ә.Әминов. *Аннары без бу «баз»дан тышка – күзләрне чагылдырып җибәргән якты язга чыктык.* Х.Сарьян

**Чагылдырып кылү** Шушы вакытка кадәр чагылдыру. *М.Гафури совет төзелешенең төрле тармаклары турында язды һәм бик күп политик актуаль вакыйгаларны чагылдырып килде.* М.Җәлил. *Шулай итеп, вакытка һәм урынга бәйле ир-ат исемнәре борынгыларның рухи тормышын, космогоник карашларын чагылдырып киләләр.* Г.Шәйхиева

**Чагылдырып китү** Нәрсәдер уңаеннан бераз чагылдыру. *Төркиләрнең галәмгә булган шундый карашын XIV гасырда Сәйф Сараи, табигый хәл итеп, үзенең шигырендә чагылдырып китә.* Р.Һади

**Чагылдырып кую** Кинәт яки бераз чагылдыру. *Кинәт карауга, күзләрен чагылдырып куйды.* М.Кәбиров

**Чагылдырып тору** Даими, әледәнәле чагылдыру; әле, хәзер чагылдыру. *Чөнки тел яшәешенең һәр тармагын, һәр тарафын, мизгелен сеңдереп, чагылдырып тора.* М.Юныс. *Алар көмеш шикелле ялык-йолык итеп, күзләрне чагылдырып тора.* Г.Мөхәммәтшин

**Чагылдырып узу** *к.* **чагылдырып китү.** *Әлбәттә, Мәмлиевләр ыруыннан булган туганнарның ачы язмышын Рушан үзенең «мәңгелек тормыш китабы»нда чагылдырып узмый калмады.* Р.Мирхәйдәров

**ЧАГЫЛМА** *и. диал. к.* **чагылыш**. *Һәм кыеш көзгедә күренгән чагылма төсле иләмсез үзгәрешләргә очрый.* Ш.Камал

**ЧАГЫЛУ** *ф.* 1) Яктылык нурлары, сынып, кире кайту; ялтырап күренү. *Көн уртасында тып-тып түбәдән тамган көмеш тамчыларда кояш чагылып китә, түбәдән ватылып төшкән боз кисәкләренең зыңгылдавында да күптән үк сагындырган яз авазы яңгырый.* Г.Бәширов. *Өстәлдәге бәләкәй көмеш үлчәүләрдә, колбаларда тәрәзәдән төшкән кояш нурлары чагылып уйный ---.* Г.Әпсәләмов

2) Яктылык шәүләсе күренү, ялтырап китү. *Шул кара суда яр буе утлары алтын баганалар булып чагылып, күлгә әллә нинди серле төс бирәләр.* Г.Әпсәләмов. *Җилсез булганга, төтен туры гына күтәрелә, пыяладай су өстендә ялкын телләре чагылып уйный.* А.Тимергалин

3) Кинәт күренеп китү; күренү. *Яшеллек эчендә көзге кебек ялтырап яткан күлләр чагылып кала.* Ф.Хуҗин. *Шулай бер көнне урман кырыенда йөргәндә, күзенә Әкмәли чагыла ---.* В.Ильясов

4) Кешенең йөзендә, хәрәкәтләрендә, сөйләшүендә рухи халәте сизелү, беленү. *Аның иреннәре, хәтта чәч көдрәләре дә калтырый, зур ачылган күзләрендә йөрәк өзгеч гаҗәпсенү, дөньяның караңгы һәм шакшы булуына чиксез аптырау чагыла иде.* А.Тимергалин. *--- адәм баласының күңеле нәкъ көзге кебек ул – эчтәге хисләр икесенең дә гамәл-кыланышларыннан ук чагылып тора ---.* З.Хөснияр

5) Берәр предметның, күренешнең асыл сыйфаты, үзенчәлеге күренү. *Ләкин кыска сузык авазларның язуда чагылмавы аркасында, сүзләрне укуда төрлелек саклана.* А.Тимергалин

6) Тормыш сәнгать чаралары белән күрсәтелү, тасвирлану. *Хәнәвинең актёр уенында тулы чагылган беркадәр дөньядан читләшкән булуы (отрешённость) аның фаҗигасы булып әйләнеп кайта.* А.Әхмәдуллин. *Җырда, сеңелем, кешенең бөтен хәсрәте дә, шатлыгы да чагыла шул.* Г.Тарханова

7) Көчле яки кинәт барлыкка килгән, яисә кайтарылган яктылыктан күзләр күрмәс булу. *Баштарак урамга килеп чыккан Сәүбән, күзләре яңа кояш нурларына чагылып, берни дә күрмәде.* Г.Гыйльманов

8) Кинәт барлыкка килү, туу (уй-хисләр тур.). *Гаҗәеп бер җитезлек белән башында уйлар чагылып, акылын яктыртып җибәргәндәй булды.* Ф.Яруллин

**Чагыла башлау** Чагылырга тотыну. *Кояш баер алдыннан, каршы йортларның тәрәзәләрендә һәм «Пампушки»ның пыяла стеналарында шәфәкъ кызыллыгы чагыла башлагач, бүлмә караңгылана, моңсулана, почмакларга эчпошыргыч күләгәләр кереп оялый.* М.Маликова. *Ә ул үзен алтмыштагы карт кебек хис итә: тәне генә түгел, аның рухы да картаеп таушалды, ул күзгә күренеп олыгайды, килеш-килбәтендә һәм йөрешендә генә түгел, уй-фикерләрендә дә бу бик нык чагыла башлады.* Р.Кәрами

**Чагылып алу** Бераз чагылу; азга гына чагылу. *Күзләрен билгесез бушлыкка тери, күз алмаларында мичнең кызгылт ялкыннары чагылып ала.* М.Мәһдиев. *Ирен читләрендә генә мәсхәрәле елмаю чагылып алды.* В.Имамов

**Чагылып бару** Эзлекле рәвештә чагылу. *Аңлатмада тикшеренү процессы чагылып барса да начар түгел, әмма ул сәнгатьле риторик сөйләмгә әверелмәсен.* Р.Әхмәтьянов

**Чагылып бетү** Тулысынча чагылу; бик нык чагылу. *Тормыш таләбеннән килеп чыккан кайбер мәсьәләләрнең безнең законыбызда чагылып бетмәгәнлеге дә мәгълүм булды.* Р.Вәлиев

**Чагылып калу** Берәр тәэсирдән чагылган хәлгә килү. *Яшен кебек ялтырап алды, Чагылып калды күзем. Яктылык зур булган саен Каравы аңа кыен.* Э.Шәрифуллина

**Чагылып килү** Шушы вакытка кадәр чагылу. *Алар сәнгатьнең һәр төрендә, аның төрле дәверләрендә, төрле агымнарында төрлечә чагылып килә.* К.Гыйззәтов. *--- вакытлы матбугатта да катнаш никахларга әлегәчә төрле мөнәсәбәт чагылып килә.* Ә.Закирҗанов

**Чагылып китү** Кинәт чагылу. *Шундый зәһәр уй чагылып китте дә, мин аны тизрәк куалап җибәрергә тырыштым.* А.Тимергалин. *Аның йөзендә чын-чынлап курку чаткылары чагылып китте.* А.Фәләх

**Чагылып кую** Кинәт чагылу; аз гына я тиз арада чагылу. *Хәтта ирен кырыйларында чак кына елмаюга охшашлы нәрсә дә чагылып куйды.* М.Хәсәнов. *Килеп басса, шул чагының кыяфәтсез гәүдәсе, йөзе, бөкресе чагылып куяр кебек.* К.Җәмит

**Чагылып узу** *к.* **чагылып үтү**. *Болдыр киләсенә ябышуга, Миңнеханның күңеленнән тагын бер уй чагылып узды ---.* В.Имамов

**Чагылып үтү** Бик аз вакыт эчендә генә чагылып юкка чыгу. *Гасимәнең балкып-янып торган йөзендә бик азга гына ризасызлык галәмәте чагылып үтте.* В.Нуруллин. *Ә Габделхәйне белгән кеше аның күзләрендә искәрмәстән аз гына вакытка чагылып үткән сагыш шәүләсен күрми калмый.* Ф.Садриев

**ЧАГЫЛУЧАН** *с.* Чагыла торган. *Җитлеккән һәр шагыйрьнең шигъри дөньясында туган илнең табигате нин-*

*ди дә булса кабатланмас бер үзенчәлеге белән чагылучан була.* Н.Хисамов

**ЧАГЫЛУЧАНЛЫК** *и. физ.* Чагылу үзлеге (яктылыкның, радиодулкыннарның)

**ЧАГЫЛЧАН** *с. диал.* Үпкәләүчән, кимсенүчән, гарьчел. *[Бу мәкаль] һәрбер гади сөйләшүдән үзенә төртке, ишарәләр эзләүче, авыру дәрәҗәсендә чагылчан булуга карата китерелә.* Н.Исәнбәт

**ЧАГЫЛЫШ** *и.* 1) Ялтырап торган шома өслектә, көзгедә, суда күренгән сурәт. *Кинәт аның күзе зур көзгедәге үзенең чагылышына төште.* И.Хуҗин. *Мин пыяладагы чагылышның әсире идем.* А.Әхмәтгалиева. *Күкләр биеклеген чамалыймын, Чагылышын күреп коеда; Озак карап торсаң, упкынына Тартып алыр сыман тоела.* И.Диндаров

2) Күз алдында, хыялда, уйда барлыкка килгән сурәт, образ. *Үткән истәлекләрнең чагылышы*

3) Чынбарлыкның сәнгать чаралары белән бирелүе, сурәтләнүе. --- *сәнгать – чынбарлыкның образлар формасындагы чагылышы да.* К.Гыйззәтов. *Ә инде Ләйлә белән Мәҗнүннең теге дөньяда да һаман кавышмаулары – әсәрдә суфичыл карашның бер чагылышы.* Дөнья цивилизациясендә татар дастаннары

4) Берәр хәл яки вакыйганың асылы, үзенчәлеге; шул вакыйгалардан килеп туган нәтиҗә күренеш. *Нинди генә кыенлыклар күрмәсен, эшләгән эш, кылган гамәлләренең нәтиҗәсе тормышта ачык чагылыш таба килә иде.* Р.Мөхәммәдиев. *Шуңа күрә Калка елгасындагы сугыш – шул тирәләрдәге вак ызгышларның бер чагылышы гына булуы мөмкин.* И.Хуҗин. *Татарда демографик проблема – шушы кризисның бер чагылышы инде ул.* Г.Шәйхи

5) *филос.* Аңның тышкы дөньяны чагылдыру үзлеге, объектив чынбарлыкны чагылдыру сәләте. *Сәнгатьнең асылын шул рәвешле билгеләү диалектик материализмның чагылыш теориясенә нигезләнгән.* К.Гыйззәтов

**ЧАГЫМ** *и. диал.* 1) Очкын

2) *к.* **сагым**. *Синең киткәнеңне карап калдым, Мине ташлаганга үкенеп. Рәшә дулкынында чагым булып, Дөнья киңлегендә югалдың.* В.Ильясов

**ЧАГЫНДА** *бәйл. к.* **чакта**. *Беләм, иң чарасыз чагында кешегә сүзсез калудан, эндәшмичә торудан да яхшырак һәм кулайрак киңәш юк.* Ф.Яхин. *Бәйрәмнең иң кызган чагында сәхнәдә гүзәл кыз пәйда була.* Р.Батулла

**ЧАГЫР** I *с.* 1) Соры, көлсу. *Чагыр ат*

2) Төрле төстәге, чуар (күзләр тур.). *Мәхүп – күрше хатыны. Чагыр күзле, тешләренә кара яккан.* Ф.Халиди. *Киеме шәп булса да, бер күзе чагыр!* Р.Батулла

**ЧАГЫР** II *и. бот.* Ташкыранчалар семьялыгыннан вак шәмәхә кызыл чәчәкле үлән үсемлек; *русчасы:* **бадан**. *Миңлебай, курайларны, чагыр үләннәрен чытырдатып изгәләп, үзенең буе кадәр булып үскән әнә шул печәнлекне үтеп чыга башлады...* Н.Яһудин

**ЧАГЫР** III *и. иск.* Кызыл аракы; исерткеч эчемлек. *Без дә, аның сүзен тыңлап, чагыр эчми, сыйланып кына кайттык.* Ш.Камал. *Ярышта Типкә би белән пир ата Әмәк тә Әгълигә берәр мичкә яңа сыра, чагыр һәм буза бирделәр.* Н.Фәттах

**ЧАГЫР** IV *и.* Су күтәргеч тәгәрмәч; куласа. *Иртәгә кичен мин үземнең атым белән әниемнең сеңеленә китәм, алар, Турмак елгасы Сафарка елгасы белән кушылган җирдә, чагыр белән сугарып бакча үстерәләр ---.* В.Ильясов

**ЧАГЫРТАШ** *и.* Су тәэсирендә шомартылган һәм түгәрәк форма алган вак таш; *русчасы:* **галька**

**ЧАГЫШТЫРГЫСЫЗ** *с.* 1) Бик яхшы, тиңе булмаган, теләсә нинди чагыштырулардан югары. *Суның алыптай көче миллиардларча сукыр лампалар уты белән чагыштыргысыз яктылык бирәчәк, хезмәт куячак.* З.Хөснияр. *Бу гүзәл кызның исеме Гөлсия булып, үзенең чагыштыргысыз матурлыгын ул кучмә төрки кабиләсеннән алган иде.* А.Нәҗми

2) Бик аерылып торган, чагыштырып булмый торган. *Безнең заман кешесенең нерв нагрузкасы борынгы кешеләрнекеннән чагыштыргысыз зур.* Г.Әпсәләмов

3) Шактый; бик; искиткеч. *Ә Рәшит абый, шахмат белеме һәм тәҗрибәсе чагыштыргысыз баерак булуга карамастан, ныграк тырышкан икән.* М.Хуҗин. *Әгәр дә нindiдер йолдызлыкта тереклек бар дип фаразласак та, алар монда килеп җитә алмыйлар, чөнки андый чагыштыргысыз зур араны үтәрлек очкыч кәнди булырга мөмкин түгел.* Ш.Алпар

**ЧАГЫШТЫРМА** *и.* **1.** 1) Чагыштыру (*1–2 мәгъ.*). *Һәрнәрсәнең үз кыйммәте, үз чагыштырмасы бар, диләр, Рушания дә үз тормышын аларныкы белән чагыштырды.* З.Кадыйрова

2) *әд. к.* **чагыштыру** (*3 мәгъ.*)

3) *мат.* Бер санны икенче санга бүлүдән барлыкка килгән өлеш. *Саннарның чагыштырмасы*

4) Аерым өлешләрнең үзара пропорциясе. --- *хәзер сыеклык массасының ризык күләменә карата чагыштырмасы 5:1 формуласы белән билгеләнә.* Ж.Юныс

**2.** *с. мәгъ.* 1) Берсен икенчесе белән чагыштыруга нигезләнгән, чагыштырып эшләнгән. – *Мин төрк телләренең чагыштырма сүзлеген төзи башладым, аның аерым өлешләрен бастырдым да инде, – диде ул.* Т.Әйди. *Галимнәр төрки телле милләтләрнең дөньяга карашына, халык әдәбиятына зур игътибар биреп, аларны өйрәнүдә чагыштырма тел белеменең мөмкинлекләрен ассызыклыйлар ---.* Г.Рәхим // *махс.* Берәр нәрсә белән чагыштырып билгеләнгән. --- *Г.Дәүләтшин төзегән чагыштырма таблицадагы печән ае да шушы чорга карый дип уйлыйбыз.* А.Тимергалин

2) Абсолют булмаган. *Хакыйкать чагыштырма булган кебек, ялган да чагыштырма нәрсә.* А.Тимергалин. *Аның, шартлы терлеккә күпме азык бирәмлеге, дигән шундый бер чагыштырма күрсәткече бар.* Г.Шәйхи

3) *махс.* Берәр җисемнең күләменә, авырлыгына яки үзлегенә карата икенче бер җисемнең күләмен, авырлыгын яки үзлеген үлчәүгә билгеләнгән. *Аның составында нindiдер бик кыйммәтле металл булса кирәк. Чөнки чагыштырма авырлыгы гаять зур.* А.Хәсәнов

**ЧАГЫШТЫРМА-ГЕНЕТИК** *с. махс.* Чагыштыру һәм генетик анализ ысулларын берләштергән, шуларга нигезләнгән. *Чагыштырма-генетик ысул*

**ЧАГЫШТЫРМАЛЫ** *с.* 1) Чагыштырмасы булган. *Метафоралы, чагыштырмалы образ-шигырьләр хакында да шуны ук әйтергә мөмкин.* Р.Кукушкин

2) Күренеш һәм фактларны чагыштырып тикшерүгә нигезләнгән. --- *төрле тел һәм шивәләрне тикшереп, бер телнең башка телләргә, шивәләргә якынлык һәм ераклыкларын ачып күрсәткәне чагыштырмалы грамматика дип атала.* Г.Алпаров

**ЧАГЫШТЫРМАЛЫЛЫК** *и.* Чагыштырма, чагыштырмалы булу. *Димәк, гүзәллекне бәяләүдә чагыштырмалылыкка да урын кала дигән сүз.* К.Гыйззәтов

**ЧАГЫШТЫРМАСЛЫК** *с. к.* **чагыштыргысыз**. *О, хәзерге ак заманда*

*кара мунчада чабынып чыгу – белгәннәр өчен берни белән чагыштырмаслык олы бәйрәм!* А.Гыйләҗев. *Димәк, аның үлемендә гаебем Гайшә әнисенеке белән чагыштырмаслык зур!* С.Баттал

**ЧАГЫШТЫРМА́-ТАРИХИ** *с.* Күренешләрне һәм фактларны тарихи яктан чагыштырып тикшерүгә нигезләнгән. *Чагыштырма-тарихи ысул*

**ЧАГЫШТЫРМА́ЧА** *рәв.* **1.** 1) Чагыштырып караганда, чагыштырганда. *Чамасыз озын тоелган гыйнвар төне чагыштырмача тыныч узды.* В.Нуруллин. *Фаргелет – чагыштырмача яшь йолдыз әле, аңа нибары ике миллиард өч йөз илле миллион йөз дә сиксән дүрт мең йөз кырык өч яшь кенә.* Г.Афзал

2) Билгеле шартлар өчен генә дөрес, яхшы; шартлыча. *Чагыштырмача яхшы эш*

3) Бераз. *Болары чагыштырмача җиңел эшләнде.* А.Әхмәдуллин. *Урал төбәге татарларының күчеш активлыгы чагыштырмача түбәнәя.* Д.Исхаков. *Шуңа күрәме, җае туры килмәдеме, инде тормышлар чагыштырмача рәтләнеп китсә дә, үз балаларына гомерендә бер генә тапкыр да «бәхет пилмәне» пешермәде...* А.Фәләх

**2.** *с. мәгъ.* 1) Нәрсә белән булса да чагыштырып билгеләнгән. *Бу очракта бәхет дигәнең исә чагыштырмача мәгънәгә ия.* З.Хөснияр. *«Төс» сүзенең чагыштырмача яңалыгы аның кайбер төрки (угыз һ.б.) телләрендә юклыгыннан яисә сирәк кулланылуыннан да күренә.* Р.Әхмәтьянов. *Бу очракта хәтта яктылык дигән нәрсә үзе дә чагыштырмача төшенчәгә әйләнеп кала.* Җ.Юныс

2) Билгеле чамадагы. *Аннан, Лилия сеңлем, шамакайлану ул – чагыштырмача әйбер.* Г.Каюмов

**ЧАГЫШТЫРМА́ЧАЛЫК** *и.* Чагыштырмача булу

**ЧАГЫШТЫРУ** I *ф.* 1) Бер әйбернең, күренешнең икенчесе белән охшашлыгын яки аермасын яисә берсенең икенчесеннән өстенлеген ачыклау максаты белән тикшерү. *Картайдым, фәкыйрьләндем, авыруга сабыштым дип, үзенең хәзерге хәле берлән иске хәле арасын чагыштырып карарга сәбәп була иде.* Г.Исхакый. *Анда кабатланулар, эчке каршылыклар очрый, әмма дәлилләр, төрле чыганакларны чагыштырып тикшерү һәм, ниһаять, система җитенкерәми.* А.Тимергалин

2) Кем яки нәрсә белән дә булса тиңләү, кемгә яки нәрсәгә булса да охшату. *Сәрвәр апа аларны бер-берсе белән чагыштырып, тиңләштереп йөдәп чыга иде.* А.Алиш. *Әмма инде бу һаваны камераныкы белән чагыштырып булмый.* И.Салахов

**Чагыштыра башлау** Чагыштырырга тотыну. *Сез чагыштырырга мөмкин булмаган нәрсәләрне чагыштыра башладыгыз.* Г.Әпсәләмов. *Мисхәт кәгазьгә кадалды, хат белән икесен чагыштыра башлады.* Т.Галиуллин

**Чагыштыра тору** Әле чагыштыру; озак вакытлар чагыштыру. *Шулай азык-төлекне чагыштыра торгач, алар кыйммәтрәк яшь икән, дигән фикергә килдем.* Безнең гәҗит. *Бөтен нәтиҗәләрне чагыштыра торгач, белгечләр өстенлек итүче ярымшар белән кәрәзле телефонны кайсы колакка китерү арасында нык элемтә булуын исбатлаган.* Шәһри Казан

**Чагыштыра төшү** Бераз чагыштыру; тагын чагыштыру

**Чагыштырып алу** Тиз арада чагыштыру. *Карадым да Синең фотосурәтеңә, чагыштырып алдым никтер үзем белән. Беләсеңме, Сәҗидә апа, мин бит Сиңа шактый гына охшаш икән йөзем белән...* Л.Мөгътәсимова

**Чагыштырып бару** Даими чагыштыру. *Күңелгә хуш килгән бер күркәм сыйфаты бар авторның: күргәнтанышканнарын, өйрәнеп күңелгә салганнарын һәрчак үзебезнең Татарстан хәлләре белән чагыштырып бара.* Б.Камалов. *Башкомандующий приказларын тәрҗемә иткәндә, аңа мин дә булышам: мин русчасын укып, ул тәрҗемәсен чагыштырып бара, тагын һәм тагын төзәтеп, аныклап, өтерфәләннәрен куеп чыгабыз.* М.Яһудин

**Чагыштырып кую** Тиз генә яки алдан чагыштыру. *Кәримә әлеге мескен кызны ирексездән үзе белән чагыштырып куйды.* З.Хөснияр. *Мөхәммәдьяр карт, үзе дә сизмәстән, бу караңгы йортны үз гомере белән чагыштырып куйды...* Г.Гыйльманов

**Чагыштырып тору** Даими яки әледән-әле чагыштыру; хәзер, әле чагыштыру. *Ул, пумаласын кулындагы чүпрәккә сөртә-сөртә, әле шушы авыл күренешенә, әле картинасына карап, чагыштырып торды.* М.Яһудин. *Аны башка балалар белән гел чагыштырып торыгыз.* Сабантуй

**Чагыштырып чыгу** Тулысынча, бер-бер артлы чагыштыру. *Аннары Разия Салахов кичергән тормыш авырлыкларын үзенең күргәннәре белән чагыштырып чыга.* А.Алиш. *Аннары идарәгә кайтып, кенәгәләр буенча нәрсәнең күпме булырга тиешлеген карап, чагыштырып чыктылар.* В.Нуруллин

**Чагыштырып яту** *сөйл. к.* **чагыштырып тору**. *Тәрбиялелек, мәдәниятлелек турында уйланам да без үскәндәге хәлләр белән чагыштырып ятам.* Безнең гәҗит

**ЧАГЫШТЫРУ** II *и. әд.* Бер нәрсәне икенчесенә охшатып әйтелгән фраза, тәгъбир, тезмә. *Җанны кош белән чагыштыру күп халыкларда таралган.* Г.Дәүләтшин

**ЧАДРА** *и. фар.* 1) Мөселман хатынкызлары өйдән чыкканда баштанаяк ябына торган җиңел өске япма, бөркәнчек. *Ишек артында аяк тавышлары, сөйләшкән авазлар ишетелә башлауга, ханым тиз генә чадрасын алып бөркәнде ---.* Р.Батулла

2) *куч.* Берәр эшкә комачаулык итеп, чикләп торган нәрсә. *Коллык чадраларының ертылып ташлануына аз гына вакыт үткән булса да, эшлекле, талантлы, матур инженер, агроном, врач, профессор, эшче, колхозчы хатын-кызлар бездә хәзер искиткеч күп бит.* Г.Кутуй

**ЧАЖ** I *иярт.* **1.** Печән чапканда һәр аерым селтәм вакытында, сыек чыбык, каеш белән бер тапкыр сукканда, зур тизлектә барган машина кисәк тукталганда һ.б. очракларда чыккан тавышны белдерә. *Әй апа, безнең тау – во тау... түбәтәйдән виың-ңң, каршы тауга дзиң-ңң, аннан соң сикертмәдән фиү-үүт, чажж, зыр-рр, шарт ---.* Р.Батулла

**2.** *рәв. мәгъ.* Бик тиз; кинәт. *Әмма күрәм: мине космик тизлекләре белән узып киткән иномаркалар, Әлмәт юлының катлаулы бер чатына җитәрәк, кинәттән тизлекләрен чаж киметеп, хәтта табан асларыннан очкыннар чыгарып тормоз салып, бер төшне кискен рәвештә әйләнеп узалар.* А.Хәсәнов. *Толыпны кидердем дә чаж мин кайту ягына!* З.Зәйнуллин

**ЧАЖ** II *и.* Күрән. *Чаж тугайлыгы – чаж (кыяк) үлән үскән тугайлык.* Ф.Гарипова

**ЧАЖГЫРУ** *ф.* 1) Бик тиз хәрәкәт иткәндә сызгырту, кычкырту (гадәттә, паровоз тур.)

2) *куч. сөйл.* Кычкыру, тупас сөйләшү. *– Син бала-чага булма, иптәш Зөбәеров, – дип чажгырды бүлек мөдире.* Ш.Бикчурин

**Чажгыра башлау** Чажгырырга тотыну. *Идарәдә бергә эшләгән иптәшләр дә колакка чажгыра башладылар ---.* Ш.Бикчурин

**ЧА́Ж ИТҮ** *ф.* 1) Чаж иткән тавыш чыгару. *[Сәхипҗамал:] Аз гына ялгыш эшләсәң я берәр шүрене төшерсәң, мачтыр кулындагы киң каеш белән чаж итеп сыздыра иде.* А.Әхмәт

2) *к.* **чаж** (*2 мәгъ.*) *Озак көттермәде Тавис, чаж итеп килеп тә керде.* М.Маликова

**ЧАЖЛА́У** *ф. к.* **чыжылдау**. *Кыз көлеп җибәрде, һәм шундук Җик Мәргән баш очында кыл арканның чажлап очуын ишетте.* М.Хәбибуллин

**Чажлап кую** Кинәт чажлау; бер тапкыр чажлау. *Беркөн Газизулла белән кайткач, минем караелан чажлап куйды да кәбестә чаба торган беләк буе пычак белән өстебезгә ыргылды.* Ф.Баттал

**Чажлап тору** Даими яки әледән-әле чажлау; әле, хәзер чажлау. *Агач бадьян белән алып, чажлап торган ташка кайнар су бөркеде.* Р.Батулла. *Кемдер таба астына утлы күмерләр китереп өйде, ул чажлап тора, ак кар өстендә дә суынырлык түгел иде.* Ф.Бәйрәмова

**ЧА́Ж-ПОЖ** *иярт.* Бик кызган табага яшелчәләр, камыр салганда, кызган ташларга, күмергә су сипкәндә чыккан тавышны белдерә

**ЧА́Ж-ПОЖ ИТҮ** *ф. к.* **чыжылдау**. *Кинәт чаж-пож иткән тавышлар ишетелде, тирә-як аксыл пар белән тулды.* Н.Дәүли

**ЧА́Ж-ПОЖ КИЛҮ** *ф. к.* **чыжылдау**. *Ә үзе мич тирәсендә кайнаша булса кирәк, таба коймагы чаж-пож килә.* Ф.Яхин

**ЧА́Ж-ЧОЖ** *иярт.* 1) Печән чапканда, пычкы белән утын кискәндә, таба кызганда һ.б. эшләр вакытында чыккан тавышны белдерә. *Инде бу тавышлар да бетте, кайсы пичтә, кайсы казанда чаж-чож пешеренергә, алып кайткан акчаның рәхәтен күрергә башладылар.* Г.Ибраһимов. *Менә, карап тор: кулыңны алмаш-тилмәш шулай алып саласың да аягыңны чаж-чож йөртәсең!* А.Гыйләҗев

2) *к.* **чыш-пыш**. *Ул, өйалды ишеген ачар-ачмас, бик ашыгып һәм борчылып, әтигә чаж-чож нидер пышылдарга тотынды.* Г.Бәширов

◊ **Чаж-чож җибәрү** Сугу. *Икесенең дә арт якларына --- чаж да чож җибәрмәсенме бу.* С.Поварисов

**ЧА́Ж-ЧОЖ ИТҮ** *ф. к.* **чыжылдау**. *Бер дә чаж-чож итмидер суккан тавыш.* Г.Тукай. *Урамнарда төрле якка ашыгып-ашыгып йөргән чит телләрдә сөйләшүче төрле халык, --- чаж-чож итеп йөргән трамвай вагоннары, куркыныч тавышлар чыгарып чапкан автомобильләр, велосипедлар...* Г.Рәфикый

**ЧА́Ж-ЧОЖ КИЛҮ** *ф. к.* **чаж-чож итү**. *Бик каты өч кәррә мылтык атылуы кияүнең капкадан керүеннән хәбәр биреп, ул арада чаж-чож килгән чана тавышы зөфаф өчен хәзерләнгән шул келәт алдына кияүнең килеп җитүен белдерде.* Г.Ибраһимов. *Чыбыклар чаж-чож килә.* Г.Әпсәләмов. *Күрәсең, ул атлар күплегеннән, тыгызлыктан һәм, чаж-чож килеп, уңлы-суллы уйнаклаган камчы авазларыннан ук кыбырсыган, миңгерәгән иде.* В.Имамов

**ЧАЖЫЛДА́У** *ф. к.* **чыжылдау**. *Бер уч сипкән саен, орлык чажылдап тубалга бәрелә дә, чәчрәп, җир өстенә сибелә.* Г.Бәширов. *Паровозлар чажылдады, буферлар бәрелде, күмер, су алдылар.* М.Мәһдиев

**Чажылдап алу** Тиз арада чажылдау. *Тыны кысылып, аз гына ял итәргә теләсә, каеш чыбыркы янә елан урынына чажылдап ала.* С.Поварисов

**Чажылдап тору** Даими яки әледән-әле чажылдау, әле, хәзер чажылдау. *Сәхип теге кылый күзле хәлфәне дә, тыгызлыкны да, аксак шәкертне дә, уңлы-суллы чажылдап торган озын чыбыкны да онытты ---.* Г.Ибраһимов

**ЧАЙКАЛДЫРУ** *ф.* 1) Бер яктан икенче якка, югарыдан түбәнгә яки башкача басып тора алмаслык итеп селкетү; чайкау. *Дебаркадерга керүемә, аны чайкалдырып, пароход килеп туктады.* Г.Тавлин. *Баскан җирем чайкалдырып җир тетрәде, Кояш сүнде, бар дөньяны сөрем күмде, Челпәрәмә килде бәхетем, җаным үлде...* Р.Вәлиева

2) Һавада селкетү, тирбәндерү; төрле якка болгау. *Көянтәләр, сиртмә төсле чайкалдырып, су китергән авылымда һәр өйгә дә...* Р.Әхмәтҗан. *Хатын чиләктәге суны, чайкалдырып, кызның аягына түкте.* Н.Гыйматдинова

3) *күч.* Икеләндерү, шикләндерү. *Тарихчыларыбыз арасындагы бетмәстөкәнмәс бәхәсләр чайкалдыра аларны.* Р.Юныс

**Чайкалдыра башлау** Чайкалдырырга тотыну. *Аз гына җил чыгып, көймәне як-якка чайкалдыра башласа, аның тәннәре калтырана, су төбенә китеп, балык карынына эләгү куркуы аның йөзенә ачык укырлык дәрәҗәдә чыга иде.* Г.Ибраһимов. *Юлия аның янына очынып килде дә кулларыннан алды һәм чайкалдыра башлады.* Ә.Мушинский

**Чайкалдыра төшү** Бераз чайкалдыру; тагын чайкалдыру. *Ольга Васильевна өстенә ап-ак халат кигән иде, сылулыгын югалткан гәүдәсен чайкалдыра төшеп, --- идәнгә шык-шык басып китеп барды.* Г.Ахунов

**Чайкалдырып алу** Кыска вакыт яисә сизелер-сизелмәс кенә чайкалдыру. *Башын бер чайкалдырып ала да янә тәмлерәк үлән эзләп китә, юаш сыерларны да ияртә үз артыннан.* С.Поварисов

**Чайкалдырып җибәрү** Көтмәгәндә чайкалдыру. *Сержант Прокофьев салны чайкалдырып җибәрүгә, Җаббаров башы белән суга чумды.* Г.Әпсәләмов. *Әйе, әйе, чытлык Филисә, көймә төбеннән су керә дип, кырыйга басты да көймәне бик нык чайкалдырып җибәрде.* Н.Хәсәнов

**Чайкалдырып кую** Кинәт чайкалдыру; бер тапкыр чайкалдыру. *Аны сәламләп, җил ботакларын чайкалдырып куйды, яфракларын кытыклап шыбырдатты.* Ф.Садриев. *Балыкчыларның көлешүе Минзәлә инешен уңгасулга чайкалдырып куйды.* Ф.Яхин

**Чайкалдырып тору** Даими яки әледән-әле чайкалдыру; әле, хәзер чайкалдыру. *Хәтта океан лайнерларын да уңга-сулга чайкалдырып торган дулкыннар җилсез-яңгырсыз көнне дә басылып тормыйлар.* А.Хәсәнов. *Бу шомлы ыгы-зыгы ошамады аңар, ул бертын, гаҗәпсенгән сыман башын кагып, мөгезләрен як-якка айкап чайкалдырып торды.* Р.Мөхәммәдиев

**ЧАЙКАЛУ** *ф.* 1) Су, җил тәэсире белән төрле якка яисә югарыдан түбәнгә таба тирбәлү. *Биш-ун минут үттеме икән, һава кинәт караңгылана башлады, самолёт чайкалырга тотынды.* Г.Әпсәләмов. *Киң, талгын, чал Идел өстендә җилкәнле кораблар, ишкәкле каеклар чайкала, ялгыз балыкчы көймәләре нокта сыман һич селкенми тора.* В.Имамов

2) Җилфердәү. *Аркылы-торкылы сузылган бауларда кибәргә эленгән марлялар һәм кемнәрнеңдер керләре чайкала.* Ә.Рәшитов. *Язгы аяз күгебездә Күгәрченнәр оча бездә, Байраклар чайкала җилдә, Ялкын кебек булып.* Р.Вәлиева

3) Дулкынлану (диңгез, иген басуы тур.). *Безнең аяк очында тын елга*

*чайкала.* С.Сабиров. *Чайкалып йоклый басулар, Башаклар йөгерәләр.* А.Хәлим

4) Сизелер-сизелмәс хәрәкәт итү. *Урман өстендә тилгәннәр чайкала.* М.Мәһдиев. *Җил чак кына тибрәтте исә, шау чәчәккә күмелгән алан буйлатып төрле төстәге дулкыннар чабышып үтә, алар өстендә уенчык җилкән шикелле күбәләкләр чайкала иде.* А.Тимергалин. *Сәгатьнең озын тимерчыбыкка эленгән борчак коймагы төсле сары теле уңга-сулга талгын гына чайкалмаса, Бикташ аны йөри дип тә белмәс иде, чөнки уклары, сумала белән ябыштыргандай, хәрәкәтсез булып тоелды.* М.Маликова

5) Дулкындай, салмак кына хәрәкәт итү. *Бөтерелгән, кайнашкан, чайкалган зал туктап калды, җыр тавышлары, шыштырдау, шапылдаулар басылды, барысы да, уртада ачык урын калдырып, читкә таралды ---.* Н.Фәттах. *Егетләр, түгәрәкне өзеп, бераз чайкалган хәлдә, бәхеттән балкыган кызлар арасына кереп, кулларын әле бербереснә, әле ботларына чабып, ярсу көйгә иярәләр.* А.Нәҗми

6) Хәлсезлектән, авырудан, көтелмәгән хәбәрдән кыйшаеп китү, ава язу. *Мифтах чайкалды. Мөршидә аны тагы да кысып тотты, аварга ирек бирмәде.* М.Хуҗин

7) *диал.* Бәрелүдән дулкынланып су түгелү, чәчрәп китү; чайпалу. *Ә чишмә, чайкалып, ярларга ташлана. Урынында тик көйгән кап-кара таш кала.* М.Җәлил

8) *күч.* Икеләнү; төпле фикергә килә алмау; үз юлын таба алмау; буталу. *Ил чайкала, йөзә кай яккадыр – Гүя Нух пәйгамбәр көймәсе.* М.Шиһапов

**Чайкала башлау** Чайкалырга тотыну. *Шул вакытта аяк астында җир чайкалып киткәндәй булды, шабырдап, салкын яңгыр коя, тирә-юньдәге агачлар чайкала башлады.* Д.Гыйсметдин

**Чайкала бирү** Бернигә карамый чайкалу. *Крейсерлары шунда рейдта чайкала бирсен.* А.Хәсәнов

**Чайкала төшү** Бераз чайкалу. *Сәлах, маңгай астыннан карап, азрак чайкала төшеп басып торды.* Г.Әпсәләмов. *Мәҗит, башына таяк белән сугып миңгерәүләтелгән кешедәй чайкала төшеп, утынлыкка таба юнәлде.* М.Яһудин

**Чайкалып алу** Бераз, сизелер-сизелмәс чайкалу; бер тапкыр чайкалу. *Минә председателебез килеп идарәгә кереп китте, озак та үтмәде, алар Асылов белән болдырга чыктылар, халык төркеме чайкалып алды.* А.Гыйләҗев. *Малай, бауга асылынган килеш, чайкалып алды да аяклары белән мәгарә авызына басты.* А.Тимергалин

**Чайкалып китү** Кинәт чайкалу. *Ул шундый каты сикерде, өстәлдәге лампа, чайкалып китеп, аз гына аумады.* Г.Әпсәләмов. *Нәрсә китереп куйсалар да, тәлинкә чайкалып китә.* А.Хәсәнов

**Чайкалып кую** Бераз, бер тапкыр чайкалу. *Әнә шул борылуы үз башына булды аның: велосипеды кинәт чайкалып куйды да, кыз да, Эшләпә үзе дә юл буендагы тузанга егылып төштеләр.* В.Нуруллин. *Музыка яңгырауга, бөтен мәйдан чайкалып куйды ---.* Г.Әпсәләмов

**Чайкалып тору** Әледән-әле яки даими чайкалу; әле, хәзер чайкалу. *Җилдә бераз чайкалып торгач, Әркәшә гөрселдәп җиргә коелды.* М.Мәһдиев. *--- имәннәр әле анда, әле монда чайкалып торалар да фырылдап, колачларын җәеп, үләннәрне изеп, вак куакларны сытып, җиргә барып яталар.* А.Гыйләҗев

**ЧАЙКАЛЫШ** *и.* 1) Чайкалу күренеше. *Янтая төшеп, сыңар кулы белән зәңгәр көянтәсен кочаклаган көйгә ашыгып китеп барган шул гәүдәнең серле чайкалышларыннан күзен ала алмый карап торды ул.* Р.Мөхәммәдиев

2) *күч.* Буталчыклык; икеләнүчәнлек. *[Әлеге] --- шартлау иминлек утравы булган бу җирләрнең инде чайкалыш һәм революция дәверенә кереп баруы турында сөйли.* Акчарлак

**ЧАЙКА́У** I *ф.* 1) Юылган әйберне сабыннан чистарту өчен, суда бер яктан икенче якка йөртү, сабынсыз гына икенче кат юып алу; пакьләү. *Сафагәрәенең киемнәрен җыр көйләп уа да Иделдә үзе чайкый иде [ул].* М.Хуҗин. *Элек ул күлдә бала-чага балык тота, ир-егетләр ат коендыра, хатын-кыз басмаларга басып кер чайкый, ул керне бәләкләп куя торган иде.* Л.Хәмидуллин

2) Чистарту яки дәвалау өчен, су яки башка сыеклык белән юдырту. *Шуннан котылып булмасмы дип, елга буена төштем дә су белән авызымны чайкый башлаган идем, тагын башым әйләнеп китеп, суга егылдым.* В.Нуруллин. *Авыз бозылса, ачуташ (бакыр купоросы) катнашмасы белән авызны чайкыйлар.* Фән һәм тел

**Чайкый башлау** Чайкый башлау. *Шулай, бөтен елганы иңләп кенә, җырлый-җырлый кер чайкый башладык.* Н.Кәримова

**Чайкый төшү** Тагын да бераз чайкау; яхшырак чайкау

**Чайкап алу** Тиз генә чайкау. *Ул арада шул ук суда кер чайкап алалар, ул арада эссе кояш астында кер кибеп тә өлгерә.* М.Мәһдиев. *Мәсәлән, азык кабул иткәч, авызны чистартып торуның кирәге юк – аны чәй эчкәндә үк быкыр-быкыр чайкап алырга була.* А.Гыймадиев

**Чайкап бетерү** Тулысынча, барысын да чайкау; кирәкле кадәр чайкау. *Бераздан мин керләрне чайкап бетердем дә, кайтып киттек.* Ф.Төхбәтуллин

**Чайкап җибәрү** Бераз чайкау. *Аннан соң океанның һавасы да икенче, тозлы су белән тамагыңны да чайкап җиффәрсәң, тавышлар ачылып китә, бер дә Илһам Шакировныкыннан ким түгел.* Н.Әхмәдиев

**Чайкап кую** Алдан чайкау

**Чайкап тору** Әледән-әле яки даими чайкау; әле, хәзер чайкау. *Йөгереп төшеп басмага керүем булды, басма уртасында иелә-иелә кер чайкап торган яшь кенә кызны күреп тә алдым.* Т.Нурмөхәммәтов

**ЧАЙКА́У** II *ф.* 1) Раслау яки расламауны, хуплау яисә хупламауны белдереп, гаҗәпләнүдән башны бер яктан икенче якка йөртү, бору. *Фельдшер аның пульсын капшап карады һәм, башын чайкап, болай икән бу, дип куйды.* Р.Кәрами. *– Хикмәт, – диде башын чайкап император Феодосий.* М.Хәбибуллин // Башны тигез рәвештә салмак астан өскә хәрәкәт иттерү. *Ул бара-бара да әле башын чайкый, әле телен шартлатып ала ---.* А.Гыйләҗев

2) Һавада төрле якка селкү, болгау. *Торналар киң канатларын мәһабәт чайкап, озын аякларын бөгеп җиргә иңеп алдылар да һава ярып күккә күтәрелделәр.* М.Мәһдиев. *Башакларын чайкый җилдә арыш, башаклары авыр, таза, тулы...* К.Сибгатуллин

**Чайкап алу** Тиз генә чайкау. *Афзалов, кистем – бетте, дигәндәй, уң кул яссысын, урак белән чайкагандай, табын өстеннән чайкап алды.* Ф.Садриев

**Чайкап ату** Кисәк кенә чайкап җибәрү. *Сәхнәгә чыгу белән, толымнарын аркасына чайкап атып, беренче аваз салуга, пышын-пышын утырган тамашачылар да шып тынып калалар, аның атлап йөрүләрен, аның бөртек сүзенә хәтле мөкиббән булып күзәтәләр иде...* Т.Нурмөхәммәтов

**Чайкап җибәрү** Көтмәгәндә чайкау. *Яруллин аягына аксап атлый, атлаган-*

*да кулын, ишкәндәге төсле итеп, аркасына таба чайкап җибәрә.* Ф.Садриев. *Таудан төшкәндә, алгы тәгәрмәч юлда яткан таш өстенә ялгыш килеп менде дә кызулык белән килүче мотоциклны чайкап җибәрде...* Ф.Яхин

**Чайкап кую** Бер тапкыр чайкау. *Кунак гаҗәпләнеп башын чайкап куйды, әмма артыгын сорашмады.* З.Мурсиев

**Чайкап тору** Әледән-әле яки даими чайкау; әле, хәзер чайкау; туктаусыз чайкау. *Хәбәр дөрес: өлкән өйнең артында көмешләнгән иярле сылу айгыр, көннең кызулыгыннан, йөрүдән тирләп, башын чайкап тора ---.* Г.Ибраһимов. *Әни беркавым башын чайкап торды ---.* Г.Бәширов

**Чайкый башлау** Чайкарга тотыну. *Чокыр-чакырлы урман юлы тарантасны шактый нык чайкый башлагач, Гөлүсә тураебрак утырды.* В.Нуруллин. *Берничә катлы йорт биеклегендәге дулкыннар «Кара Акула» корабын якорьдан өзәргә әзер булып чайкый башлаганнар.* Көмеш кыңгырау

**Чайкый тору** Әлегә чайкау; озак чайкау. *Атлар, печәннәрен ашап бетергәннән соң, чебен белән кигәвен тешләүгә чыдый алмыйча, тып та тып тибенәләр, тынычсызланып башларын чайкый торгач, йөгәннәрен салып, күршеләре белән тешләшергә, чинашырга тотыналар.* Г.Бәширов

**Чайкый төшү** Бераз чайкау. *Егет, озын чәчен чайкый төшеп, Әлфиягә борылды.* А.Расих

**ЧАЙНВОРД** *и. ингл.* Бер-берсенә чылбыр рәвешендә (беренче сүзнең соңгы хәрефе икенчесенең беренче хәрефе тәртибендә) бәйләнгән җавапларны берләп артлы килгән шакмакларга урнаштырудан гыйбарәт башваткыч. *Шигырь юлларын укып чыкканнан соң, чайнвордка аның исемен языгыз.* Ватаным Татарстан. --- *катыргы тартманың тышында бизәлгән чыршы формасында чайнворды да бар.* Әлмәт таңнары

**ЧАЙПАЛДЫРУ** *ф.* Савытны селкетеп, бәрдереп һ.б. эчендәге сыеклыкны азрак түгеп җибәрү. *Мирвәли, ашлы тәлинкәсен чайпалдырып, өстәл уртасынарак этте һәм урындыгын аударып аягына басты.* А.Гыйләҗев. *– Бетәргә тиеш түгелие, – дип караңгыда башын чайкады Зөфәр һәм, машинаны як-якка селкетеп, бактагы бензинны чайпалдырды.* И.Хуҗин

**Чайпалдыра тору** Берникадәр вакыт чайпалдыру; әле чайпалдыру. *Сулы тәлинкәне чайпалдыра торгач, бал су белән кушылып бетте дә кечкенә кәрәзләр формасына керде дә куйды.* Шәһри Казан

**Чайпалдыра төшү** Бераз чайпалдыру

**Чайпалдырып алу** Тиз арада чайпалдыру. *Их, ул укытучыларның август конференцияләре! Мамадышның җанын дулкынландырып, күңелен чайпалдырып ала.* Р.Газиз

**Чайпалдырып җибәрү** Кинәт чайпалдыру. --- *шигырь ахырында гына бөтен тулылыгында ачылып киткән гөнаһсыз бер сабый трагедиясе укучы күңелен тәмам тутыра, чайпалдырып җибәрә. М.Вәлиев*

**Чайпалдырып кую** Бераз чайпалдыру

**Чайпалдырып тору** Әледән-әле яки даими чайпалдыру; әле, хәзер чайкау; туктаусыз чайпалдыру

**ЧАЙПАЛТУ** *ф. к.* **чайпалдыру**. *Нәҗип, мөлдерәмә тулы бидонын чайпалтмаска тырышып, аяк астын күзе белән капшый-капшый, шактый озак кайтты ---. А.Гыйләҗев. Шулкадәр каты чәкештерәләрмени, чайпалттың бит. Ф.Садриев*

**Чайпалта тору** Берникадәр вакыт чайпалту; әле чайпалту

**Чайпалта төшү** Бераз чайпалту

**Чайпалтып алу** Тиз арада чайпалту

**Чайпалтып җибәрү** Кинәт чайпалту. *Чикләвек яртылай киселгән, һәм аның эчендәге сыекча, әзрәк чайпалтыбрак җибәрсәң, түгелергә дә мөмкин иде.* Ахир

**Чайпалтып кую** Бераз чайпалту

**Чайпалтып тору** Даими, әледән-әле чайпалту; әле, хәзер чайпалту. *Аның әле үз янәшәсендә таяк очы белән агымсуларны чайпалтып торуыннан файдаланып, малайның инәсе белән ике арада булган бәхәсне чишеп каласы килде.* А.Хәлим

**ЧАЙПАЛУ** *ф.* 1) Савыты бәрелү яки селкенеп кую аркасында сыеклык чәчрәү, түгелү. *Камыт агачы шыгырдый, мичкәдә су чайпала, арба ераклаша, әмма Сафый абзый бәхетле.* М.Мәһдиев. *Кыз, чайпалып түгелмәсенгә чиләкләрен кулы белән тотып, гәүдәсе белән ярты-лаш миңа таба борылган иде.* Ф.Хуҗин

2) *күч.* Бик нык борчылу; капма-каршы характердагы төрле хисләр кичерү. *Давытның күңеле әле бер якка, әле икенче якка чайпалды, әле төшенкелеккә бирелде, әле, ярсып, дуамалланып, баш күтәрде...* Г.Гыйльманов

**Чайпалып алу** Бераз чайпалу. *Сыекланган ми чайпалып алды.* М.Мәһдиев

**Чайпалып китү** Бераз чайпалу. *Кымшанса, чак кына кыймылдаса, күңеле тулы мөлдерәп торган хистойгысы чайпалып китәр, түгелер, юкка чыгар кебек иде.* М.Хәбибуллин. *Кулындагы сөтле чиләгә кинәт чайпалып китте, кыз беләгендәге тастымалын күкрәгенә кысты.* В.Имамов

**Чайпалып кую** Кинәт чайпалу. *Симез корсагы чайпалып куйды.* А.Толстой

**Чайпалып тору** Әледән-әле яисә даими чайпалу; әле, хәзер чайпалу. *Бәхет касәләре тулып, чайпалып торган көннәрнең үткәне сизелми дә.* Н.Көбәш

**ЧАЙРА́У** *ф. диал. к.* **җәйрәү**. *Ә Наилә чайрап йоклый, әйтерсең мәрткә киткән.* В.Нуруллин. *Янәшәдә генә Казансу елгасы нурланып чайрап ята, дугалы күпере өстеннән машиналар агымы туктамый.* Н.Хәсәнов

**ЧАК** I *и.* 1) Билгеле бер яшь арапыгына туры килгән вакыт, кайдадыр яшәгән ара, чор. *Яшьлегемне уйлап сагынам да Юләр чагым күреп үкенәм. Әй бер Аллам, Сиңа табынам да, Тигез картлык бир, дип үтенәм.* В.Галиев

2) Берәр эш-хәл булган вакыт аралыгы. *Йөгереп чыктым урамнарга, – Кояш батар чак җиткән.* Ф.Зыятдинова. *Ул вакытларда, үзегез дә аңлыйсыз, хәзерге кебек, шаулатып, кунак-муйнак уйный торган чаклар түгел.* Ф.Яхин

3) Гомумән вакыт. *Мондый чак кызыну өчен әйбәт түгел түгелен, ультрашәмәхә нурлар аз була, ләкин башка бер эш юк...* А.Тимергалин

**ЧАК** II *рәв.* 1) Көчкә, авырлык белән. *Ишек төбендә күзләрен уып утыручы Гадел үзенең кайдалыгын чак аңышты.* Г.Гыйльманов. *Директорны хәзергә тавышланмый торырга, милиция чакыртмаска чак күндерде ул һәм башына килгән бердәнбер уен тикшереп карарга булды.* З.Мурсиев

2) Аз гына; бераз; җиңелчә. *Җитмәсә тагы, чак кына яктылык сирпелә башлау белән, элек берсе, аннары икенчесе, аннары бишенчесе, аннары унбишенчесе – чебен кузгалды.* Ф.Хөсни

3) Берәр эшнең аз гына булмый калуын белдерә. *Соңгысында Мәмдәл, янып, чак кара күмергә калмаган.* А.Хәсәнов. *Медальон астында чокып ясалган түгәрәк ояда яшел нәрсә күренгәч, Таймасның йөрәге кагарга тотынды, буфет эченә чак кереп китмәде малай.* А.Тимергалин

**ЧАК** III *с. сөйл.* **1.** Таман, төгәл туры килгән. *Чак кием*

**2.** *хәб. функ.* Җитеп бетми, таманрак, чамалы. *Столовой кызларының Чисталыгы чаграк.* Х.Туфан

◊ **Чак булу** Кылган эшенә бик туры килү турында. **Чак кирәк** *к.* **чак булу**

**ЧАК** IV *с. диал.* Начар, эшәке (кеше тур.)

**ЧАКАЛ** *и. иск.* Чүл бүресе, шакал. *Арыслан белән юлбарыс талашканда, чакал тук булыр.* Мәкаль

**ЧАКА́Л ӨРЕГЕ** *и.* Кыргый кара җимеш

**ЧАККЫЧ** *и.* **1.** 1) Кайбер төр бөҗәкләрдә, хайваннарда тидереп, тешләп алуга кешеләргә, хайваннарга агу җибәрергә мөмкинлек бирә торган әгъза, күзәнәк; ук, чага. *Аларның чаянныкы кебек койрыклары һәм чаккычлары бар иде, һәм аларга шушы койрыклары белән биш ай буе кешеләрне газапларга хак бирелде.* Инҗил

2) Кайбер үсемлекләрдә төкчә. *Кычыткан чаккычы*

**2.** *с. мәгъ.* Чага торган. *Эчәккуышлыларга чаккыч күзәнәкләр һәм ашкайнату куышлыгы булу хас.* Биология

**ЧАККЫЧЛЫЛАР** *и. күпл. зоол.* Чаккыч күзәнәкләре булган эчәккуышлы хайваннар; *русчасы:* **стрекающие**

**ЧАКЛАК** *и. диал.* 1) Ком һәм чуерташ белән капланган урын

2) Сазлыктагы чоңгыл, сыек баткаклык. *Чаклакка килеп керү*

**ЧАКЛЫ** *бәйл.* Хәтле, кадәр. *Алтыга чаклы санаьйм, качып өлгермәгән кеше көтүче була.* Р.Батулла. *Биргән вәгъдәләрем үтәлмәгән, Эшләнәсе эшләр тау чаклы.* Ф.Зыятдинова

**ЧАКЛЫК** I *и. сөйл.* Акыл җитеп бетмәү. *Картлык – чаклык.* Мәкаль

**ЧАКЛЫК** II *и. диал.* Начарлык, эшәкелек

**ЧАКМА** *и.* **1.** 1) Чакматашка бәреп, кискен тидереп алып очкын чыгара торган корыч кисәге. *Чакма чагып ут үрләтү, ау элмәге, ятьмә, бумеранг, сакма, җәя, арба тәгәрмәче, тегермән чарыгы, сал һәм көймә, җилкән кебек нәрсәләрне картаеп буыннары каткан адәмнәр түгел, һичшиксез, кыбырсык балалар уйлап тапкан, кыргый җәнлекләрне дә алар кулга иялэштереп, ач вә ялангач инсаниятне атлы вә сыерлы иткәннәр.* А.Тимергалин

2) Утлы коралларда ударникның атканда патрон капсюлен вата торган очлаеп килгән өлеше; *русчасы:* **боёк**. *Солдатлар мылтык чакмаларын чакылдаткалап, команда көткән бер рәвешкә кerделәр.* М.Галәү

3) *сөйл.* Чакматаш белән ата торган мылтыкның йозагы. *Исмәгыйль мирза, ашыкмыйча гына, кыска мылтыкның чакмасын киерде.* Р.Батулла

4) Ут кабызып җибәрү өчен шырпы урынына кулланыла торган җайланма; кабызгыч, зажигалка. *Ул төтенсыман соры төстәге каптан бер сигарет тартып чыгарды, затлы чакмасын чыкылдатты.* Р.Мирхәйдәров

**2.** *с. мәгъ.* Каты, үзсүзле. *Ул Фазылҗан Җангирович белән озак еллар эшләгәнгә, аның холкы чакма икәнен, үз сүзеннән кайтмаячагын яхшы белә иде.* Г.Әпсәләмов

**ЧАКМАЛЫ** *с.* Чакмасы булган; чакматашлы. *Кораллар бүлегендә чакмалы пистолетлар, хәнҗәрләр, кистәннәр...* Г.Сабитов

**ЧАКМА́ МАМЫГЫ** *и. иск.* Үрләтеп җибәрү өчен әзерләнгән мамык (чүпрәк), ку гөмбә яки башка коры, тиз кабынучан әйбер; *русчасы:* **трут**. *Матвей, бик каушап, чакматаш, корыч кисәге һәм чакма мамыгы салынган янчыгын чыгарды. Казан утлары*

**ЧАКМАТАШ** *и.* Ут чыгару өчен кулланыла торган каты таш; *русчасы:* **кремень**. *Әлтафи – класста иң зур малай, аның кесәсендә һәрвакыт чакматаш белән филтә һәм бакчада үстергән яшел тәмәке булыр.* М.Мәһдиев. *Утсыз калган чакта, Ничек очкын чыгарасын Чакматаштан сора!* Ф.Зыятдинова

**ЧАКМАТАШЛЫ** *с.* Чакматашы булган. *Гомеремдә беренче мәртәбә мин шунда чакматашлы озын мылтык күрдем.* В.Имамов. *Әйтик, ул заманнарда чакматашлы мылтыклар, дары белән атучы пушкалар булган.* Ватаным Татарстан

**ЧА́КРА** *и. санскр.* Индуизм һәм парапсихологиядә: тәнендәге биоэнергияне туплаган һәм кешенең яшәү көче белән идарә итә торган энергия үзәге. *Минә аның түбәсендәге яктылык төененнән (моның чакра дип аталганын Сәбилә соңыннан белде) баягыдан югарак нур көлтәсе үсеп чыкты.* З.Мурсиев. *Аннан кайткач, кешенең зиһене дә яхшыра, ди, космос белән бәйләнешкә керә икән дә, чакрасы ачыла, ди.* Г.Тарханова

**ЧАКРЫМ** *и.* 1) Метрик система кертелгәнче кулланылган озынлык үлчәве (1,06 км га тигез). *Лизалар моннан ун көн әүвәл N шәһәреннән ике-өч чакрым ераклыктагы бер җиргә дачага чыкканнар, һәм аның бүгенге килүе, дачага чыкканнан соң, әүвәлге килүе иде.* Ф.Әмирхан. *Вагоннар астында рельслар, тукы-тукы килеп, чакрым арты чакрымнарны саный.* Ф.Хуҗин

2) *сөйл.* Километр. *Авыл белән авыл арасы ике чакрым гына*

**ЧАКРЫ́М БАГАНАСЫ** *и.* 1) Чакрым исәбен күрсәтә торган багана; *русчасы:* **верста, верстовой столб**. *Олы юл буена чакрым баганалары гына куела.* А.Тимергалин. *Юлның җимерелгән урыннарын төзекләндерергә, тракт буена чакрым баганалары куярга, өлешчә сакланган таш күперне яңартырга кирәк булачак.* Алабуга нуры

2) *күч.* Озын буйлы кеше

**ЧАКРЫМЛАП** *рәв.* 1) Чакрым исәбе белән, чакрым белән исәпләп. *Араны чакрымлап үлчәдек*

2) Алда күрсәтелгән сан кадәр чакрым ераклыкта, аралыкта. *Авылдан Күке тавына кадәр – чакрымлап ара.* Г.Гыйльманов. *Беренче көнне, урманнар арасыннан бара торгач, кырык чакрымлап юл үтәләр.* З.Мурсиев

**ЧАКРЫМЛЫК** *с.* Саннар янында килеп, шул кадәр чакрым озынлыгында, ераклыкта булганны белдерә. *Ул – моннан утыз чакрымлык җирдә элгәре үзе эшләп үзе ашаган берәүнең матур, яшь, сөекле хатыны иде.* Г.Ибраһимов. *Әйтергә онытканмын: илле чакрымлык метро да төзергә кирәк булыр.* Ф.Баттал

**ЧАКТА** *бәйл.* 1) Берәр зат, кеше башкарган эшнең, вакыйганың вакытын икенче зат үтәгән эш-вакыйгалар аша белдерә; вакытта. *Кышкы кичләрнең балалар өчен иң күңелле, иң куанычлы сәгате, ихтимал, шәфәкъ баткан чакта башланадыр.* Г.Бәширов. *Фәтхерахман карт исән чакта мондый ыгызыгыны белмәгән председатель Әхмәдулла хәзер көн саен атлар яныннан бер урый торганга әйләнде.* В.Имамов

2) Бер зат, нәрсә башкарган эшхәрәкәтнең вакытын шул ук зат, нәрсә башкарган икенче эш-хәрәкәт аша белдерә. *Яки, язып утырган чакта, бер җиргә килеп төртеләсең дә ары таба алып китә алмый интегәсең.* В.Нуруллин. *Нефтьчеләр, әлеге паркны сүткән чакта, аларга коймa булып хезмәт иткән бу тимерчыбыкны тураклаганнар да, кая туры килсә, шунда ташлап киткәннәр.* А.Хәсәнов

**ЧА́К-ЧАК** *рәв.* 1) Көчкә, көч-хәл белән. *Чак-чак сулыш алып яткан бу малай актыгы үзенең язмышын үзе күп-*

*тән хәл иткән инде.* Г.Гыйльманов. *Үзебез балта чапкан яшь ботакта Чак-чак кына эләгеп торабыз...* Ф.Зыятдинова

2) Аз гына. *Мәхмүт элек дарга менгән Пәри Рәистән чак-чак кына кайтыш.* В.Имамов

**ЧА́К-ЧОК** *иярт.* Металл, ат тоягы һ.б. металл яисә ташка бәрелгәндә, тигәндә чыккан тавышны белдерә

**ЧА́К-ЧОК ИТҮ** *ф.* Чак-чок килгән тавыш чыгару

**ЧА́К-ЧОК КИЛҮ** *ф. к.* **чак-чок итү**

**ЧАКЫЛДА́У** *ф.* Металлга, ташка металл, гомумән каты әйберләр үзара бәрелешеп өзек-өзек авазлар чыгу. *Смычогын ыргытып җибәреп, скрипкасын сәке читенә шулхәтле каты бәрде: скрипка бик нык чакылдаган тавыш чыгарып, кисәкләре кайсы кайда тузылып китте...* Ш.Камал

◊ **Чакылдап торган** Сөйләшкәндә чын мишәрчә [ч] авазын яңгыратып әйтүче кеше турында. *Безнең шул мишәрдәге кыз чәүкә кебек чакылдап торган өч мишәр малае үстерә.* З.Зәйнуллин

**Чакылдап кую** Бер тапкыр чакылдау

**Чакылдый башлау** Чакылдарга тотыну. *Коридорда конвойчыларның дагалы итекләре чакылдый башлады.* Казан утлары

**ЧАКЫРГЫЧ** *с.* **1.** *физ.* Чакыру өчен хезмәт итә торган. *Чакыргыч аппарат*

**2.** *и. мәгъ.* Чакыру өчен хезмәт итә торган аппарат. *Чакыргыч куллану*

**ЧАКЫРТУ** *ф.* Икенче кеше аша, хат аша яки элемтә чаралары ярдәмендә чакырып китерү. *Берничә сәгать үтүгә, эскадрилья командиры үзенә чакыртты.* Ф.Хуҗин. *Атам Бабур падишаһ Шираздан да, Тәбриздән дә, Дәһлидән дә, Аһра каласыннан да осталар чакыртты.* Р.Батулла

**Чакырта башлау** Чакыртырга тотыну. *Кирәкми, карчык, бил чатнаган саен табиб чакырта башласаң, алдар күкегә әйләнерсең.* Сөембикә

**Чакырта тору** Бик озак, бик күп тапкырлар чакырту.*Чакырта торгач, бер салмыш мастер килеп чыкты да суыткычыбызны төзәтеп куйды.* Шәһри Казан

**Чакыртып алу** Тиз арада килеп җитәргә дип чакырту. *Гәүһәршад йомышчысын чакыртып алды.* М.Әмирханов

**Чакыртып йөрү** Озак вакытлар чакыртып тору. *Кыз башым белән урядник янына чакыртып йөрсәләр...* Н.Яһудин

**Чакыртып тору** Даими яки әледән-әле чакырту; әле, хәзер чакырту. *Көн саен диярлек Чаллыга киңәшмәгә чакыртып торалар.* Э.Касыймов. *Коншактан, Чиләбедән табиблар чакыртып торабыз, бу чирләрнең нидән икәнен, ничек дәваланырга кирәклеген сорыйбыз.* Ф.Бәйрәмова

**ЧАКЫРУ** I *ф.* 1) Тавыш, ишарә яки берәр сигнал белән якынлашырга, килергә кушу, үтенү. *Яулыклы хатын, имән бармагы белән ишарәләп, мине үз янынарак чакырды.* А.Тимергалин

2) Берәр җиргә нинди дә булса максат белән барырга, килергә өндәү. *Ике көннән соң безне каравыл өенә чакырдылар.* А.Шамов. *Бөтен авыл халкын бәйрәмгә чакырабыз!* А.Гадел

3) Берәр эш башкарырга тәкъдим итү. *Сәрандиб (Цейлон) атавындагы бәйнәлмиләл савыктыру үзәгенә баш табиб итеп чакыргач, ул, авыр кичерешләрдән арынырга өметләнеп, җәннәттән атабыз Адәм сөрелгән шушы гүзәл утрауга күчеп китте.* А.Тимергалин

4) Шәхси бурычны яки вазифаны үтәргә тарту. *Мин инде җиткән җегет булдым, менә берничә елдан патша хезмәтенә чакырырлар.* Г.Ибраһимов. *Киресенчә, без сезне туган илебезгә хезмәт итәргә чакырабыз.* А.Хәсәнов

5) Билгеле бер эш, фикер йөртүгә, тырышка өндәү; дәгъвәт итү. *Ул патшаның бу эшен күреп, аңа каршы чыга, аны Аллаһ диненә чакыра.* А.Гайнетдинов

◊ **Чакырып алу** Эштән азат итү, эш урынын бушатырга кушу. *Илчене чакырып алу*

**Чакыра башлау** Чакырырга тотыну. *Якташына ничек кенә булса да ярдәм итәргә теләгән Микола аны үзенә – ниндидер Раздольноега чакыра башлады.* А.Хәлим. *Рөстәм түзми, Хикмәт бабайны чакыра башлый.* А.Гадел

**Чакырып алу** Үз янына чакыру; тиз арада килеп җитәргә кушып чакыру. *Беркөнне, эшчеләр төшке ашка туктагач, комсомол ячейкасы секретаре Кадыйрны үз бүлмәсенә чакырып алды, аңа үзе утыра торган урындыкны бирде.* А.Алиш

**Чакырып бетерү** Һәммәсен чакыру; чакырып йөдәтү. *Әллә нинди түрәләр катына чакырып бетерерләр иде ---.* М.Әмирханов. *Кайбер очракларда һәр баланы да чакырып бетерә алмыйбыз, чөнки бүләкләр турында да уйларга кирәк.* Безнең гәҗит

**Чакырып кую** Көтмәгәндә чакыру; алдан ук чакыру. *Озатканда мин анарга, Дәргачка килә калсаң, миңа да җитеш, диеп кабат чакырып куйдым.* В.Ильясов

**Чакырып тору** Даими яки әледән-әле чакыру; әле, хәзер чакыру. *Бар ди сиңа, коймак пешереп, табагачларын юллыкка тыгып болгап чакырып торалар!* А.Гыйләҗев. *Коесының сиртмәле булуын, әллә кайлардан күренеп, чыңрау торна сыман сайрап, чакырып торуын тели ул.* А.Хәлим

**Чакырып чыгу** Һәммәсен тоташтан чакыру. *Ат өстендә гаскәриләрне йөреп, һөҗүмгә чакырып чыккач, Атилла хан алдан әзерләнеп куелган калкулыкка күтәрелде һәм тагын дошман ягына күз салды.* М.Хәбибуллин

**Чакырып яту** *сөйл. к.* **чакырып тору**. *Ә Сания анда ярдәмгә чакырып ятса?* В.Имамов

**ЧАКЫРУ** II *и.* Бәйрәмгә, тантанага чакырып язылган кәгазь; чакыру кәгазе, дәгъвәтнамә. – *Чакыру җибәрделәр, зур бәйрәм үткәрергә җыенасыз икән... – генә дия алды.* А.Хәйретдинова

**ЧАКЫРУ́ КӘГАЗЕ** *и. к.* **чакыру** II. *Бу – Фәхринең үтерелүе турында булачак хөкемгә Җамалины шаһит ясап чакыру кәгазе иде.* Г.Ибраһимов. *Мин бу өлкәдә эш иткән галимнәргә чакыру кәгазе дә тараттым инде.* М.Хәбибуллин

**ЧАКЫРУЛЫ** *с.* Чакырылган, чакыру кәгазе белән килгән яки килергә тиеш булган. *Алар, киенеп-бизәнеп, театрларга, чакырулы банкетларга йөргәннәр.* А.Хәсәнов

**ЧАКЫРУ́ ЯЗУЫ** *и. к.* **чакыру** II. *Кеше аркылы гына бик тиз абыйга чакыру язуы җибәрә.* Казан утлары. *Көннәрдән бер көнне миңа телефоннан сөйләшергә элемтә бүлегеннән чакыру язуы килде.* Безнең гәҗит

**ЧАКЫРЫЛЫШ** *и.* Берәр идарә органына сайланган вәкилләрнең бер сайлаудан икенче сайлауга кадәр эшләү чоры; шул чорда эшләгән вәкилләр составы. *Егерменче елларда ул өлкә партия конференцияләренең, Татарстан Советлары съездларының һәрберсенә диярлек катнашып килде, берничә чакырылыш ТатЦИК члены, партия өлкә комитеты члены, Казан шәһәр Советы депутаты булды.* Г.Ибраһимов. *Котлы Мөхәммәднең торыны Батыр Гали Тәфкилев 1850 елда туган, 1917 елгача патша армиясе генералы, Дәүләт думасының 1, 2, 3, 4 чакырылыш депутаты.* Р.Батулла

**ЧАЛ** *с.* **1.** 1) Чәч, төкләр турында: ак төскә кергән, агарган, көмешсыман.

*Мөнирнең «әйдүк» диюенә, ишектә Казимирның чал башы күренде.* А.Хәсәнов. *Гомер юлыңны тәмамлап килгәндә чал сакалыңа «карак» дигән яманат ябыштырсыннар әле...* А.Гыйләҗев

2) Агарган чәчле. *Күрешергә килгән чал Ананың Кайнар яшен йотып, Төн үтә...* М.Шабаев. *Көймәче ишкәкләрне үзенә алды, гомер иткән чал картның Зур Суда берьеллык кына булса да тәҗрибәсе бар иде.* З.Хөсни́яр

3) *диал.* Ак таплары да булган соры төстәге, бурлы. *Маңгаенда һәм томшыгында ак тап булган атны кашка дип (Мәхмүд Кашгарида – угар ат), ак аяклы атны чаптар дип атыйлар («ялы һәм койрыгы чал булган, аксыл җирән ат» дигән билгеләмә дә бар).* А.Тимергалин

4) *күч.* Борынгы, күптәнге, карт. *Аларда бит үткәннәрнең, чал тарихның сулышы саклана.* А.Мансуров. *Әкрен генә килгән җиреннән биек меңьяшәр чал имән янында аяклары үзеннән-үзе тукталып калдылар.* А.Нәҗми

**2.** *и. мәгъ.* 1) Чәч, төкләрдәге ак төс; ак төскә кергән чәч, төк. --- *сөйкемле йөзен бераз чал кергән бөдрә сакал бизәгән бер ир уртасы чыкты.* А.Хәсәнов. *[Ханым] Ирнең чал куна башлаган чигә чәчләрен, олпат кыяфәтен, килешле сакал-мыек бизәгән йөзен төбәлеп диярлек өйрәнеп чыкты.* А.Әхмәтгалиева

2) Карт, өлкән кеше. *Сәбәбен беләсең килсә, сукыр чалның сүзен тыңла.* Г.Ибраһимов. *Җыела чаллар, аклы-каралы сакаллар, юристлар, туристлар, артистлар ---.* К.Кәримов

**ЧАЛА** *с. диал.* **1.** 1) Аралаш; бер көчәеп, бер әкренәеп ява торган. *Болыт ала булса, яңгыр чала булыр.* Әйтем

2) Ике милләт вәкиленнән туган, метис. *Чала казакъ*

**2.** *рәв. мәгъ.* Тиешле таләпләргә җавап бирмәслек итеп, җитешсез итеп; начар. *Чала гына эшләү*

**ЧАЛАРУ** *ф.* Өлешчә яки тулысынча чал төскә керү. *Ул чаларган башкаен чайкады.* А.Тимергалин

**Чалара башлау** Бераз чалару, чалару билгеләре күренү. *– Ала-а-ай! – диде ул, мин бөтенесен аңлатып биргәннән соң, чалара башлаган мыегын сыпырып.* В.Нуруллин. *Аның чалара башлаган куе чәчләре баеп барган кояш нурларында ялкынланып дөрли, какча йөзе дә ничектер яшәреп, алсуланып киткән.* А.Вергазов

**Чалара төшү** Тагын да яки бераз чалару. *Тик кызыбызның чәчләре тагын да чалара төшкән иде.* М.Хәсәнов

**Чаларып бетү** Бик нык чалару. *Врачлар хәзер чаларып беткән башыңны кисеп, кире тегеп куярга да күп алмыйлар.* М.Зарипов

**Чаларып килү** Акрынлап чалару; чалара башлау. *Инде сакалың чаларып килә, гөнаһларыңны вакыт җиле уңдыргандыр...* А.Гыйләҗев

**Чаларып китү** Соңгы арада чалару; күзгә күренеп, сизелерлек чалару. *Кичә соры мәче сыман күренгән каен толымнары чаларып киткән – кыш аларга, соңгы истәлек итеп, ак мамык шәлен япкан.* Ш.Галиев

**Чаларып тору** Чаларган хәлдә булу; чал булып күренү. *Кәпәчен --- чаларып торган башына киде.* А.Хәлим

**ЧАЛБАР** *и. фар.* Гәүдәнең билдән түбән өлешен һәм аякларны каплый торган ике балаклы өс киеме; гадәттә, ирләрнең көндәлек киеме. *Алачак акчаны кайларга тоту турында да баш вата ул: егерме сумы өйгә, ун сумы чалбар алырга, ашаудан артканы өйгә кайтканда баеп кайтыр өчен сума җыярга китәчәк...* А.Алиш. *Егетен кыздан аерырлык түгел: ялдай чәчләр җилферди, чалбар балаклары капчыктан киңрәк.* А.Гыйләҗев

◊ **Чалбар кисү** Ир баланы сөннәткә утырту. *– Масра бабаң кызыл чалбар кисә, – дип юмалап, алдап, нәни Галиәсгарне урын өстенә сузып салалар.* Р.Батулла

**ЧАЛБА́Р-КҮЛМӘК** *җый. и.* Чалбарлар һәм күлмәкләр; кием. *Танылган романист, бу бүлмәгә килеп урнашу белән, барча кием-салымының – чалбар-күлмәк, костюм, җилән сәдәфләрен, кисеп, тәрәзәдән ата.* А.Хәсәнов

**ЧАЛБАРЛЫ** *с.* 1) Чалбар кигән. *Күз алдыңа китер әле: председатель өстәл почмагындагы кнопкага имән бармагы белән басуга, чалбарлы секретарь кыз ыспай корпусын боргалап килеп керә һәм шунда ук Камил Кәримовны чакырырга чыгып та китә.* М.Галиев

2) Кием комплектына чалбар кергән, чалбар һәм тагын ниндидер башка киемнән торган. *Үтте гомерем, кия алмадым, дип, Бер чалбарлы костюм мин генә. Гел күлмәктән йөрим, кем ничектер, Шулай йөрү ошый үземә.* К.Булатова. *Быел модага ирләр стилендәге чалбар һәм чалбарлы костюмнар кире кайта.* Мәйдан

3) Тубыкларына йон үскән (әтәч, күгәрчен һ.б.ш. тур.). *Берсе чуар, икенчесе чалбарлы ак әтәч дөньяларын бетереп сугышалар иде.* С.Рафиков

**ЧАЛБАРЛЫК** *с.* **1.** Чалбар тегү өчен билгеләнгән; шуңа җитәрлек. *Февральдә командировкага чыкканда гына кырык сигез сумга алган бөрмә билле җылы туны һәм чалбарлык отрезы бар иде.* Ш.Маннур. *– Мине бүген җыелышта бик зурладылар: ике кызым белән карчыгыма күлмәклек ситса, улым белән икебезгә чалбарлык полсукно бүләк иттеләр, – дип, Нуриман абзый култык астына кыстырган төргәген күрсәтте.* Х.Сарьян

**2.** *и. мәгъ.* Чалбарга дип алынган материал. *Чалбарлыкларның английскиләре бар...* К.Тинчурин. *Шул казакилек, чалбарлык алсаң җитәр.* Г.Исхакый

**ЧАЛБА́Р ПУТАСЫ** *и.* Чалбарның билне буып торган югары өлеше. *Ачуы чыккандыр инде: тиз генә чалбар путасыннан эләктерде дә баш аркылы сыртка салмакчы булды бу мине.* Хезмәт даны

**ЧАЛБА́Р-ЫШТАН** *и. җый.* Чалбар һәм ыштан; чалбар кебек өс киемнәре. *Шунда Булат тагын бер мәртәбә ах итте: аның каршында, чалбар-ыштаннарын рәтли-рәтли, күрше авыл малае Дилүс басып тора иде!* Г.Гыйльманов. *Киемнәренә килгәндә исә, чынлап та, телевизордан күренгән кадәресе бер дә финалга үтәрлек түгел иде шул: карачкы кебек, капчык сыман күлмәк, чалбар-ыштан, чалма сыман нәрсәләр үтә дә караңгы төсләрдән сипләнгән.* Б.Рәхимова

**ЧАЛГЫ** I *и.* **1.** Үлән һәм иген чабу өчен, озын сапка утыртылган, бераз кәкре озын пычактай авыл хуҗалыгы коралы. *Чалгы чыңлаган тавыш инеш буендагы әрәмәләрдән кайтаваз булып яңадан әйләнеп менә дә басу өсләренә таралып юк була.* Г.Бәширов. *Кемдер балта саплаган, кемдер чалгысын печән өстенә таптап куйган.* В.Нуруллин

**2.** *с. мәгъ.* Шул коралның тимереннән ясалган. *Түрдә караңгы чырайлы Гафиятулла бабай, бөтен икмәкне күкрәгенә терәп, чалгы пычак белән телеп утыра.* Г.Әпсәләмов. *Ләкин иртәгесен, чәчен бабасының чалгы пәкесе белән кырдырып алган такыр башлы абыйсы капкадан чыгып киткәндә, аңа да моңсу, бик ямансу булыр.* З.Хөсни́яр

◊ **Чалгы кебек** Бик усал, үткен, зәһәр. *Теле дә аның чалгы кебек: кыеп кына ала.* А.Хәлим. **Чалгы кебек чабу** Барысын бердән, бик тиз арада юк итү, үтереп ташлау; кыру. *Монда хәзер исән калуга бернинди өмет юк: йогышлы авы-*

*руларны берничек тыя алмыйлар, гомер булмаган тиф, ваба, түләмә чирләре кешеләрне чалгы кебек чаба.* Ф.Бәйрәмова

**ЧАЛГЫ** II *и. муз. тар.* XV–XVI гасырларда төрки халыкларда кулланылган кыллы музыка коралы. *Чалгы чалу*

**ЧАЛГЫ́-СӘНӘК** *җый. и.* Чалгы һәм сәнәк; чалгы, сәнәк кебек эш кораллары. *Ләкин нигездә чалгы-сәнәк белән коралланган крестьяннар, билгеле инде, Меллинның 850 солдаттан гыйбарәт регуляр командасына каршы тора алмый ---.* В.Имамов

**ЧАЛГЫ́-ТЫРМА** *җый. и.* Чалгы һәм тырма; чалгы-тырма кебек эш кораллары. *Мәйданны үтүгә ук демонстрантлар, байракларын сабына урап һәм, печән өмәсеннән кайтучылар чалгы-тырмаларын күтәргән шикелле, иңнәренә салып, кайсысы кая таралыша башладылар.* А.Тимергалин

**ЧАЛГЫЧ** *и. бот.* Әвернәчәчәклеләр семьялыгыннан телгәләнгән яфраклы, сары чәчәкле бер-ике яки күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* **гулявник**

**ЧАЛГЫЧУТ** *и. бот. к.* **чалгыч**

**ЧАЛГЫЧЫ** *и.* Чалгы белән печән чабучы кеше. *Чалгычылар тирәсендә чуар күлмәкле хатын-кызлар печән җыя, печән әйләндерә.* М.Галәү. *Бригадир чалгычыларны борчак чабарга җибәрде, ә җыючы кызлар эскертчеләргә булышырга тиешләр иде...* Ф.Яруллин

**ЧАЛДОН** *и. монг.* Себергә беренче булып, качкын, каторжан һ.б.ш.га кадәр күчеп килгән һәм шулар нәселеннән булган рус кешесе. *Ә киржаклар, чалдоннар? Саный китсәң, бик күп алар.* Р.Зәйдулла. *Кемдер чалдон итеп саный бирсен, ә миңа син күптән үз инде.* З.Мансуров

**ЧАЛДЫР** *иярт.* Металл, таш, пыяла бер-берсенә яисә шундый ук материалдан ясалган әйбергә бәрелгәндә чыккан тавышны белдерә

**ЧАЛДЫ́Р ИТҮ** *ф.* Чалдыр кебек тавыш чыгару

**ЧАЛДЫРТ** *иярт.* Металл, пыяла кебек нәрсә кисәк төшеп киткәч, бәрелгәч чыккан кыска тавышны һәм кисәк төшеп китү рәвешен белдерә

**ЧАЛДЫРТ ИТҮ** *ф.* Чалдырт кебек тавыш чыгару

**ЧАЛДЫ́РТ КИЛҮ** *ф. к.* **чалдырт итү**

**ЧАЛДЫРУ** *ф.* Урак яки чалгы белән кистереп алу. *Мин, беләкләремдәге ташып торган ярсу көчне кая куярга белмичә, озын-озын атлап, зур-зур чалдырып урам.* Г.Бәширов

**Чалдырып алу** Тиз генә чалдыру. *Әкрәм кари берничә адым читкәрәк китеп иелде дә читек-кәвеш кигән аякларын аерып басты, урагы белән бер уч арыш сабагын чалдырып алды.* М.Галәү

**ЧАЛДЫ́Р-ЧОЛДЫР** *иярт.* Металл, таш, пыяла бер-берсенә яисә шундый ук материалдан ясалган әйбергә кабат-кабат бәрелеп торганда чыккан тавышны белдерә. *Ирем, хәләл ирем, әллә кайларда... кош очып җитмәс җирләрдә богаулы аягы белән чалдыр-чолдыр таш кисә торгандыр...* Г.Исхакый. *Низамнамә үзенең рамнары, пыялалары белән түбәнгә – таш идәнгә төшеп чалдыр-чолдыр ватылып та өлгерде, шул ук секундта ватылган пыялалар өстенә аксыл-сары шинельле, җиз төймәле, мылтыклы, кылычлы жандарм офицер – ротмистр килеп тә басты.* Г.Ибраһимов

**ЧАЛКА** I *с.* Ак таплары булган соры; гәүдәсе кара, ялы һәм койрыгы аксыл төстәге яки, киресенчә, гәүдәсе ачык төстәге, ялы һәм койрыгы кара төсле (ат тур.). *Ат төсләре: ак, акбүз, алмачуар, --- чагыр, чал, чалка, чуар, чел, чөлкәр, җара, җирән һ.б. (барысы утыздан артык).* А.Тимергалин

**ЧАЛКА** II *и.* Судноны дебаркадерга бәйләү өчен аркан

**ЧАЛКАН** *рәв.* Аркага, арка белән, өскә карап. *Закирның һәр эчүендә җенләнү, котыру һәм сүгенү гадәте булса да, хәзер аның буыннарына аракы төшкәнгә, күп котыра алмый, алай-болай омтыла башласа, чалкан төшә иде.* Г.Ибраһимов. *Без Закир абый белән кулларны баш астына куеп чалкан яттык та күк йөзендәге эреле-ваклы җемелдек йолдызларга текәлдек.* Г.Бәширов. *Хәле бетсә, чалкан йөзгән.* Г.Рәхим

◊ **Чалкан салу** Көрәштә аркасына егып салу. **Чалкан ыргыту** 1) *к.* **чалкан салу**. *Аны алышта чалкан ыргытырдай бәдәнлеләр безнең Тәмтүбәдә бөтенләй дә юктыр.* В.Имамов; 2) Бик нык тәэсир итү; уздыру; буйсындыру. *– Сәләх, – диде теләсә кайсы ирне чалкан сала торган тавыш белән Сәлимә Усмановна ---.* Р.Газиз. *Канатлы ат кебек яз килде дә Чалкан салып екты карлы кышны.* Х.Латыйф

**ЧАЛЛАНУ** *ф. сөйл. к.* **чалару**. *Берни юк... Заман җилендә Чалланган ак башым бар.* И.Юзеев

**Чаллана бару** Торган саен күбрәк чаллану

**Чаллана башлау** Чалланырга тотыну. *Аның юантык гәүдәсе кечерәеп киткәндәй булды, әле яше кырыкка да китмәгән булуына карамастан чаллана башлаган кара чәчләрен сыпыргалап алды да ---.* Р.Ишморатова. *Тәрәзә буенда аксыл йөзле, чаллана башлаган чәчле мөлаем хатын кофта бәйләп кайта.* Ф.Шәфигуллин

**Чаллана төшү** Бераз чаллану

**Чалланып бару** Торган саен акрынлап чаллану; чаллана башлау. *Чәчләре чалланып бара торган ирнең урам буйлап ялантәпи китеп баруы сәер күренәдер.* Шәһри Казан

**Чалланып бетү** Тулысынча чаллану. *Чалланып бетте чәчең.* Рухи мирас

**Чалланып китү** Кинәт чаллану

**Чалланып чыгу** Бик тиз һәм тулысынча чаллану. *Бигрәк тә Сафуан моны авыр кичерде, хурланды, кимсенде, хәтта чигәсендәге чәчләренә чаклы чалланып чыкты.* Ә.Салах

**ЧАЛМА** *и.* 1) Гадәттә дин әһелләренең махсус баш киеме: баш яки баш киеме тирәли тигез итеп кат-кат уралган озын тар тукыма. *Моның өстендә, тегеләрнеке шикелле, алтын белән укаланган җиләннәр дә, якут ташлар белән бизәлгән чалмалар да, энҗе-мәрҗән тезелеп киткән кынлы хәнҗәр аскан алтын аеллы каешлары да юк.* В.Имамов. *Монда кемнәр генә юк: кара карга канатыдай чем кара тәнле негрлар, мулатлар, башларына чалма ураган гарәпләр, кара мыеклы төрекләр, испаннар, итальяннар, французлар – һәркайсы үзләренчә кәсеп итә.* А.Хәсәнов

2) *күч.* Күпереп, кабарып торган нәрсә. *Зур, биек тәрәзәләрнең бер ягыннан – офыккача җәелгән күгелҗем диңгез, икенче ягыннан болыт чалмаларына уралган Ай-Петри тавы күренә.* Р.Низамиев

**ЧАЛМАБАШ** *и. бот. к.* **чалмачәчәк**. *Гаҗәеп матур тау икән. Итәгендә ал, зәңгәр чәчәкләр дулкынлана, чалмабашлар йөгерешә.* Ә.Маликов. *Чәчәкләрнең татарча атамалары: чалмабаш, алтын чәчәк, әдрәс гөле, чукмарбаш, ала миләүшә, ягъни елан күзе, сазанак, чабыр үләне, үрмә рәйхан, япон кынасы, кына гөле, гөлчәчәк ---.* Ш.Галиев

**ЧАЛМА́ БҮРЕК** *и.* Өстенә чалма чалына, чалма белән бергә киелә торган, аңа нигез булган бүрек. *Сезнең якка, бәлки, намазлык, комган, сөлге, эскәтер, чалма, чалма бүрек шикелле нәрсәләр дә китә торгандыр?* Г.Камал. *Икенче бервакыт Сафи карт ертылып эштән чыккан зур чалма бүреген миңа*

*«бүләк» итмәкче булгач, бу каз оясын ни эшләтим мин, дип, үзе алдында ук бер хәерче картка ыргыткан идем.* Г.Ибраһимов

**ЧАЛМАЛЫ** *с.* **1.** 1) Чалма кигән, чалмасы булган. *Карт, Сәгыйдь керүгә, бик кызып сөйләгән сүзен кисте; һәммә кеше кызгылт төсле, зур кара ачык күзле, куе кара сакаллы, ак чалмалы, яшел кием кигән Сәгыйдькә караштылар.* Г.Гобәйдуллин. *Урам тулы чалмалы, чапанлы халык гаеттән кайта ---.* Г.Рәхим

2) Чалма формасында булган, кабарып, күпереп торган. *Ак чалмалы нарат – минем вәзир, Тик ул миннән бераз ятсына – Сөйләшми.* М.Шабаев. *Мин алсу чалмалы тукранбаш өзеп, аның тәмле суын суырырга тотындым.* Г.Бәширов

**2.** *и. мәгъ.* Ислам дине әһеле; мулла-мөәззин. *Берзаманнар чалмалыга кадергыйззәт бар иде...* Г.Тукай. *Кәрим ахунның мәһабәт гәүдәсе ишектә күренү белән, залдагы чалмалыларның дәмулла булып җитмәгән муллалары урыннарыннан кузгалып юл бирделәр – ахун белән карины түргә уздырдылар.* М.Галәү

◊ **Чалмалы баш** *иск.* Сату аракысы, шешәсе сургыч белән пичәтләнгән аракы. *Чалмалы баш күтәреп, ирең тирәсендә буталулар буа буарлык!* Р.Хәмид. **Чалмалы карак** Тышкы яктан тыйнак күренгән карак. *Теге Биктимер малае килгән иде, нигә минем хатынга никах укыдың, мин сине, чалмалы каракны, судка бирәм, төрмәгә яптырам, дип әйтә, ди.* Т.Гыйззәт. **Чалмалы карга** *иск.* Садака эстәүче мулла. *Әй, кара әле, син дә чалмалы карга буласыңмы, үләксә чукырсың!..* Ә.Еники. **Чалмалы козгын** *к.* **чалмалы карга**. *Нигә тулган чалмалы козгын зиярәт өстенә?* Г.Тукай. *Сүз ала чалмалы козгын да. Юмалый карт имам ---.* Ә.Маликов

**ЧАЛМАЛЫ́ ГӨЛ** *и. бот.* Кашкарыйчалар семьялыгыннан ак, ал чәчәкле, уртасы сары төстәге бер яки күпьеллык үлән үсемлек; мәрвәрит; *русчасы:* **маргаритка**. *Чалмалы гөлләр үстерү*

**ЧАЛМАЛЫ́ ПЕСНӘК** *и. зоол.* Песнәкчәләр семьялыгыннан башында йоннары тырпаеп торган кечкенә генә сайрар кош; бүрекле песнәк; *русчасы:* **гренадёр**

**ЧАЛМА-ЧАПАН** *и. җый.* Чалма һәм чапан. *Төреп чалма-чапаннарны, Йөресәм кыр-япаннарны, Онытмам сез наданнарны ---.* Г.Кандалый. *Шулай мәсхәрә итеп утыралар иде, чалма-чапан киенгән бер өлкән адәм килеп керде.* Г.Ибраһимов

**ЧАЛМАЧӘЧӘК** *и. бот.* Чалмабашчалар семьялыгыннан җете кызыл, алсу яки ак эре чәчәкле декоратив үлән яисә куак үсемлек. *Еллар үтүдән, җилдән, яңгырдан ул тәмам каралып, бурсып беткән, эченә үләннәр белән бергә ап-ак чалмачәчәк үскән.* Г.Әпсәләмов. *Ихата эчендә никадәрле чәчәк түтәлләре! Чалмачәчәк, дәлия, гөлчәчәк, гладиолус...* В.Имамов

**ЧАЛМАШТЫРУ** *ф. сөйл.* Берсе өстенә берсен аркылы-торкылы кую (аяк, кул тур.). *Көчкә сөйрәлеп, түр сәкегә үрмәләп менә дә аякларын аркылы-торкылы чалмаштырып утыра бирә.* А.Вергазов

**ЧАЛМАШУ** *ф. сөйл.* Аркылы-торкылы килү. *Җеп чалмашып көрмәләнгән, төйнәлеп [куянның] муенында кипкән.* Н.Исәнбәт

**ЧАЛПАЮ** I *ф. диал.* Тазару, симерү. *Кыз яхшы җиргә төшсә – чалпая, яман җиргә төшсә – картая.* Мәкаль

**ЧАЛПАЮ** II *ф. диал.* Янтаю, кыйшаю

**ЧАЛПУ** *и. этн.* Ырым тексты язылган яисә беркетелгән тукыма кисәге. *--- егылган җиргә чалпу ташлау йоласы булган.* А.Тимергалин

**ЧАЛТ** I *иярт.* Гәүдәнең йомшак җиренә уч белән сукканда, берәр әйбер суга төшкәндә, тәкергәндә чыккан тавышны белдерә. *Эссе сулы мунчаланы алдым да битенә – чалт!* Г.Камал. *Учка төкереп аламын да Чалт! – дошманның яңагына!* Г.Афзал

◊ **Чалт берне** Көтмәгәндә каты итеп сугу. *Каршы дәшкән идем, яңакка чалт берне!* Х.Камалов. *Ялгыш сүз әйттеме – чалт берне!* А.Гыйләҗев

**ЧАЛТ** II *кис.* 1) Бөтенләй, тулысынча; бик (аяз күк йөзе, һава һ.б. тур.). *Чалт аяз көн, һава җиңел ---.* А.Гыйләҗев. *Казах, үзбәк, таҗик, кыргыз, төрекмәннең аллы-гөлле кояш нурлары, тавис кошы каурыйлары, елның бөтен әйләнәсендә диярлек чалт зәңгәр күк йөзе төсен яраткannарын белмиләр булыр безнең мода кайгыртучылары-быз.* Б.Рәхимова. *Аның бер ягы – чалт тигез, ялтыравык көмеш белән йөгертелгән.* Ф.Яхин

2) Төсләр янында: җете, бик. *Болар өстенә тагын әллә ничаклы ак, зәңгәр Урта Азия кәләпүшләре, чалт кара ефәктән яки укалап эшләнгән Казан кәләпүшләре, кыйммәтле камчат бүрекләр тезелгәннәр.* Г.Ибраһимов

**ЧА́ЛТ ИТҮ** *ф.* Чалт кебек тавыш чыгару. *Син таш ыргытасың, таш чалт итеп суга барып төшә.* А.Алиш. *Сергеев Дөмәй старшинаның йөзенә чалт итеп төкерде дә, усал җикереп, унтерофицерга әмер бирде ---.* В.Имамов

◊ **Чалт итеп тору** Бик яхшы, менә дигән булу. *Тешләп кара – чалт итеп торган нержавейка (аның эче тимер икәнен син күрмисең бит)!* Шәһри Казан. *Кыз сүз артыннан кесәгә керә торганнардан түгел, чалт итеп тора.* Безнең гәҗит

**ЧА́ЛТ-ЧОЛТ** *иярт.* Гәүдәнең, тәннең йомшак җиренә уч белән берничә тапкыр сукканда, су тамып торганда, кабат-кабат төкергәндә, вак металл кисәкләре үзара бәрелешеп торганда чыккан тавышны белдерә. *Түбәндә, аскы калакларга бәрелеп, чалт-чолт су чәчри, өстән тамчы тамып тора.* С.Сабиров. *Таң тишегеннән үк келәткә йөзен чытып, тирә-юньгә чалт-чолт төкеренеп килеп керде [ул].* В.Имамов. *Тиле Хәтимә сөякле кулы белән чалт-чолт аларның учына сукты.* Н.Гыйматдинова

**ЧА́ЛТ-ЧОЛТ ИТҮ** *ф.* Чалт-чолт кебек тавышлар чыгару. *Толымына үреп элгән чулпылары чалт-чолт итеп кенә тора.* Н.Дәүли. *Хисап төймәләрен чалт-чолт итеп чутлый башлыйлар.* В.Юныс

**ЧА́ЛТ-ЧОЛТ КИЛҮ** *ф. к.* **чалт-чолт итү**

**ЧА́ЛТЫР** *иярт.* Пыяла ватылганда яки металл тәңкәләр бер-берсенә бәрелеп алганда чыккан тавышны белдерә

**ЧАЛТЫРАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **чалтырау**. *Саҗидә, почта юлаучы атларының кыңгыравы кадәр зур чулпысын чалтыратып, исле сабын белән кул юарга чыгып китте.* Г.Исхакый

2) Бик каты яшен яшьнәү; яшен тию. *Тагын күк гөрелдәде, тагын яшен чалтыратты да, чиләктән койган шикелле итеп яңгыр яварга тотынды...* Ф.Әмирхан. *Ул арада тагын чалтыратып яшен яшьнәде, һәм орып яңгыр яварга тотынды.* В.Нуруллин

3) Гадәттә уч белән каты итеп сугу. *Әгәр Гали Кадыйров, йөрәге җитеп, хәзер бу ишек катына килсә... яңагына чалтыратам бер!* А.Гыйләҗев. *Гомергә башлы малай бул да, Казан университеты йөзенә калын папка белән чалтыратып куып чыгарсын әле!* Р.Газиз

4) *сөйл.* Телефоннан шалтырату. *Райкумнан чалтыраттылар.* В.Нуруллин

**Чалтыратып алу** Бик тиз генә чалтырату. *– Умри! – диде дә, күз ачып йомганчы, тегенең яңагына чалтыратып та алды.* Р.Кәрами

**Чалтыратып җибәрү** Көтмәгәндә чалтырату. *Тегенең ябык яңагына берне чалтыратып җибәрәсе урында «что сез, Рәмзи Гарипович, үпкәләтәсез бит инде» генә диде дә, шуның белән вәссәлам.* В.Нуруллин. *Еландай бөгәрләнеп, зәп-зәңгәр яшен чалтыратып җибәрде.* Р.Фәизов

**ЧАЛТЫРА́У** *ф. к.* **чылтырау**. *Чалтырап, пыяла коелганы ишетелде.* Р.Батулла. *Чалтырап, табак-савыт ватылганы ишетелде.* Ф.Яхин

**Чалтырап алу** Бер тапкыр яки тиз арда чалтырау

**Чалтырый башлау** Чалтырарга тотыну. *Тик минә ирләргә дә, хатыннарга да зур самавырлар бирелеп, чынаяклар чалтырый башлагач кына, ул инде түзмәде, бик ялынып, Фәтхия әбигә карады ---.* Г.Ибраһимов

**ЧА́ЛТЫР-ЧОЛТЫР** *иярт.* Пыяла ватылып яки металлдан эшләнгән вак нәрсәләр бер-берсенә яки каты өслеккә бәрелеп-бәрелеп алганда чыккан тавышны белдерә. *Маэмай бара күргәзмәгә: Муенсада Чалтыр-чолтыр Медальләре Ялтыр-йолтыр!* Ш.Галиев. *Кояш баеп эңгер иңгәнгәме, кибетчеләр чалтыр-чолтыр ишекләрен яба, челтәрле тәрәзәләренә богау йозакларын эләләр.* М.Хәбибуллин

**ЧА́ЛТЫР-ЧОЛТЫР ИТҮ** *ф.* Чалтыр-чолтыр тавышлар чыгу, чалтырау. *Ашка килгән егетләр чәкчәкне авыз иткәннән соң, һәркем хәле хәленчә, чәкчәк котлап, табынга алдан ук куелган җиз подноска яисә зур тарелкага, чалтыр-чолтыр итеп, көмеш тәңкәләр салалар.* Т.Гыйззәт

**ЧА́ЛТЫР-ЧОЛТЫР КИЛҮ** *ф. к.* **чалтыр-чолтыр итү**. *Абыйсының медальләре аяк атлаган җайга чалтыр-чолтыр килә.* М.Мәһдиев. *Авыр зынҗырларның чалтыр-чолтыр килүен ишеткәндәй буласың.* А.Тимергалин

**ЧАЛУ** I *ф.* Терлек сую. *Тавыкмы, казмы, күркәме – күзенә нәрсә эләгә – тота да чала, йолкый, пешекли, камыр баса, токмачын кисә, ашын пешерә ---.* А.Хәлим // Корбан гаете көнендә, Аллаһ ризалыгы өчен яисә бирәр төрле ышануларга нигезләнеп, терлекне корбан китерү. *Җитмәсә, ураза бетеп гает җиткән, ягъни үзен мөселман санаган кеше мотлак рәвештә корбан чалырга тиеш.* З.Мурсиев

**Чала башлау** Чалу эшенә керешү. *Ислам кануны буенча, бәйрәм намазыннан соң корбан чала башлыйлар.* Туган як. *Кыш айларында бик күпләр мал чала башлый.* Кайбыч таңнары

**Чалып ату** Тиз арада яки рәхимсез рәвештә чалу. *Оча поезд йолдызлы чатлардан, йоклый вагон – чалып аткандай!* Р.Әхмәтҗан. *Һушсызларны, аңсызларны чалып ату авырмыни!..* Р.Харис

**Чалып бетерү** Барысын да чалу. *Аллага шөкер, алар бездә бихисап күп, чалып кына бетерерлек түгел үзләрен.* Ф.Дәүләтбаев. *Авылларда эре терлекләрне инде чалып бетерделәр.* Ватаным Татарстан

**Чалып җибәрү** Кисәк чалу. *Үзе шундук, йөгереп барып, җан бирергә өлгермәгән дуңгызны чалып җибәрде.* Г.Гыйльманов

**Чалып ташлау** *к.* **чалып ату**. *Мостафа аны чебеш урынына чалып ташлаган булыр иде.* А.Хәсәнов. *Нуркасыйм, Нуркасыйм, чалып ташлыйммы бу үләксәне?* Д.Салихов

**Чалып тору** Әле чалу; бер-бер артлы чалу. *Мин чалып торам, хатын эшкәртә.* Авыл офыклары

**ЧАЛУ** II *ф.* 1) Бер аякны икенчесе өстенә кую. *Ул, берәүгә дә карамыйча, гитараны ала да, санын арткарак ташлап, аякларын чалып, чын музыкант кыяфәте белән берничә мәртәбә тартып куя...* Г.Ибраһимов. *Ботын-ботка чалып торуын әйт син...* Г.Гыйльманов

2) Хәрәкәтләнгәндә кешене сөртендерү, егу өчен, аның аягына үз аягын аркылы кую. *Берәрсеннән кыен ашыймы, дәүрәк малайлар аяк чалып егамы, аягына шырпы кадаламы, муен тамырына учлап тузан тутыраларммы – Хәкимҗан беркайчан да еламас, тик челт-челт күзләрен генә йомар иде.* Г.Бәширов. *Рәфгатьнең кысынкырак күзләренә ут сыймый, тышка сирпелә, мин дә Чулакны чалып егарга, безне бүгеннән салып таптаганы өчен, ипи шүрлегенә менеп төшәргә әзер.* А.Гыйләҗев

3) Берничә кат, өсте өстенә чорнау. *Иртәгә менә мулла абыең үзеңә чалма чалып бирер.* Г.Исхакый. *Ары бара, бире килә, Чалма чала, җилән кия ---.* Г.Афзал // Бау, аркан һ.б.ш. нәрсәләрне, өстәге катын астагысы өстенә салып, сүтелмәслек итеп уратып бәйләү. *Ниһаять, пароходны юан арканнар белән чуен бүкәннәргә чалып куялар.* А.Тимергалин. *Юкәсен абзар баганасына чалып аркан ишкән карт белән аның арасында менә шундыйрак сөйләшү булып алды ---.* А.Хәлим

4) Бәйләгәндә күзне сул як энәне җеп белән әйләндереп алып ясау. *Сул яктан бәйләгәндә чалып алган күзләрне уң белән бәйләргә.* Кәеф ничек?

**ЧАЛУ** III *и.* Кышкы юл кырыеның авышкан чана читкә тартыла торган урыны; салу. *Юлның электәге чалуларын соңгы бураннар шыплап күмгән.* М.Хуҗин. *--- атлар да, камытлары бүген кисмәгән икән дә, ыңгырчаклары сыртларын кырмаган, арба тәртәләре тәҗедән читкә каермаган, чана табаннары чалуларга бирешмәгән икән дә – шуңа шат, канәгать.* Ә.Гаффар

**ЧАЛУ** IV *и. диал. к.* **чалулык**. *Балалар ат сакларга җәй буе диярлек йөриләр, һәр төркемнең үзләре сайлаган чалулары, уйсулыклары бар.* Т.Нәбиуллин

**ЧАЛУ** V *ф. иск.* Музыка коралында уйнау. *Дагстанлы карт һаман саз чалып утыра...* Ш.Камал

**ЧАЛУЛАНУ** *ф.* Чалулар (III) барлыкка килү

**ЧАЛУЛАТУ** *ф.* Транспортны кыйшайтып, юлдан таеп китәргә мәҗбүр итү; салулату. *Бара-бара да, чананы бик чалулатмаска тырышып кына, дөп-дөп юыртып та китә иде.* Р.Төхфәтуллин. *Чананы нәкъ тау төшкәндә чалулатырга маташа.* А.Хәсәнов

2) *күч.* Икенче якка бору. *Ләкин әлеге шул оялчанлыгым мине урамның икенче ягына чалулатып алып китте.* Г.Бәширов

**Чалулатып алу** Бераз чалулату

**Чалулатып җибәрү** Кинәт чалулату

**ЧАЛУЛА́У** *ф.* 1) Чалулы юлда таеп кыйшаю, янтаеп китү, салулау (транспорт чарасы тур.). *Машина як-якка чалулап бара.* Г.Әпсәләмов

2) Читкә китү; юлны ялгыштыру

3) *күч.* Үз кыйбласы булмау; төгәллек сакламау, әле бер, әле икенче төрле фикер йөртү. *Җавапларда чалуламау*

**Чалулап алу** Бераз чалулау. *Бәрелешү ул кадәр каты булмады кебек үзе, чөнки машинаның чак кына чалулап алуыннан тыш берни тоймады ул.* Р.Мөхәммәдиев

**Чалулап китү** Кинәт чалулау. *Председатель Сафин атында чаптырып барган көйгә, чанасы чалулап китеп, егылган да муенын сындырган...* Р.Мөхәммәдиев. *Бер борылышта чана бер*

*якка чалулап китеп, чана табаны каткан кар өеменә бәрелде.* Казан утлары

**Чалулап тору** Гел, һәрвакыт чалулау

**Чалулый башлау** Чалуларга тотыну. *Мотоцикл көпчәкләре күрер күзгә генә коры күренгән юлдан тая, чалулый башлады.* А.Хәлим. *Моңарчы җай гына барган чананың әледән-әле чалулый башлавы яңа бер уен, яңа кызыкка сәбәпче булды.* Р.Мөхәммәдиев

**ЧАЛУЛЫ** I *с.* Чалулары булган; салулы (кышкы юл тур.). *Фатихтан мәгънә чыкмагач, Хаҗиәхмәт белән Сабир карт, юлның чалулы урыннарын айкап, Каракош сыртын берничә тапкыр урадылар.* Г.Галиев. *Чалулы юлдан барган чана кебек, баркас әле уңга, әле сулга ташлана, елга төбенә бәрелеп, бөтен корпусы белән сикереп-сикереп куя.* С.Сабиров

**ЧАЛУЛЫ** II *с.* Чабынлыклы. *Иренмичә шул чирәмле, чалулы битләүгә барып чыксаң, аякларың үзләреннән-үзләре сине калкулыкка әйди.* С.Лашманчы

**ЧАЛУЛЫК** *и. диал.* Болын; чабынлык. *Авылның старостасы белән муллага гына өстәмә бирәр имана, аннары староста ярдәмчесе белән мөәззингә бирәр дисәтинә җир өстәлә. Шуның өстенә аларга берәр чалулык та бирелә.* Т.Нәбиуллин

**ЧАЛЧЫК** *и. диал.* Баткак. *Чулманның төбе чалчык, ярлары кызыл балчык.* Җыр

**ЧАЛШАЙТУ** *ф. сөйл. к.* **чалышайту**. *Мине күргәч, икесе дә авыз чалшайттылар ---.* А.Гыйләҗев

**ЧАЛШАЮ** *ф. сөйл. к.* **чалышаю**. *Аның йөзе, иреннәре чалшайды, күзләре ялтырап китте.* Г.Әпсәләмов. *Як-якка чалшаям, ияр булмагач шуа да, әле ярый корсагы зур мескен алашаның, аның «мичкәсен» бар көчемә аякларым белән кысам.* З.Хөснияр

**ЧАЛЫК** *с.* Артак, елдам (ат тур.)

**ЧАЛЫМ** *и.* 1) Кемгә яки нәрсәгә булса да өлешчә, бераз охшашлык. *Салихымның чалымы, йөреше бар аңарда.* А.Гыйләҗев // Нәрсәнең, кемнеңдер икенче берәүдә яки нәрсәдәдер сизелерсизелмәс булган билгеләре. *Кыяфәтендәге балалык чалымнарының эзе дә калмаган.* В.Нуруллин. *Аларда тәртип, уяулык чалымнары бөтенләй юк.* В.Имамов. *Яз чалымы – кышта!* Г.Морат

2) Кыяфәт, төс-бит. *Сез мине исемем-фамилиям белән хәтерләмисез дә, ә чалымым белән хәтерләргә тиеш кебек.* Г.Әпсәләмов

**ЧАЛЫМЛА́У** *ф.* Чалымнардан тану; берникадәр охшашлык табу. *Чокыр эче сумала төтене шикелле бик караңгы булса да, Сал-Сал аны барыбер чалымлады.* В.Имамов

**Чалымлап алу** Тиз арада чалымлау. *Үзе елмайгач, чалымлап алам.* Ш.Галиев

**Чалымлый башлау** Чалымларга тотыну. *Без аны 80 нче, 90 нчы еллардагы милли күтәрелеш нәтиҗәсендә чалымлый башлаган идек.* Ватаным Татарстан

**ЧАЛЫМЛЫ** *с.* Нәрсәгәдер яки кемгәдер охшаш; кемнеңдер чалымнары булган. *Аны күргән кешеләр, нәкъ әтисе чалымлы кыз, диләр.* Безнең Чирмешән

**ЧАЛЫНУ** I *ф.* 1) *кайт. юн. к.* **чалу**. *Кабаланып атлагангамы, әллә ярның текәрәк җире туры килдеме – аяклары чалынды.* К.Кәримов

2) *төш. юн. к.* **чалу**. *Анысы да, капма-каршы чалынып, ак яулыкка төйнәлгән.* А.Хәлим

**Чалына төшү** Бераз чалыну

**Чалынып бетү** Бик нык чалыну

**Чалынып китү** Кинәт чалыну

**ЧАЛЫНУ** II *ф.* Төсмерләнү, шәйләнү, күзгә күренгәндәй, колакка ишетелгәндәй булу. *Бер адәмнең акрын сүзе колагына чалынды, алда берничә карачкыл шәүләләнде, кыз һаман барды...* Г.Ибраһимов. *Ят кеше күзегезгә чалынмадымы*? А.Гыйләҗев. *Үзләре хисле, дәртле шаян җыр җырлыйлар, ә күз карашларында сагыш, йөзләрендә, кемгәдер үпкәләгәндәй, караңгылык чалына...* В.Нуруллин

**Чалына башлау** Чалынырга тотыну. *Кайбер кызык хәлләр, төштәге шикелле, өзек-өтек кенә минем колакка да чалына башлады.* Г.Бәширов. *Ак халатлы санитар һәм санитаркаларның йөгерешкәннәре күзгә чалына башлады.* Г.Әпсәләмов

**Чалына тору** Даими чалыну, еш чалыну. *Ул университетны тәмамлаган вакытта, бигрәк тә шәхес культы фаш ителгән 1956 елда, язучылар, галимнәр арасында гаепсезгә юк ителгән яки төрмәләрдә, сөргеннәрдә тотылган әдипләребез аклана икән, аларның әсәрләре дә җәмәгатьчелеккә кире кайта икән, дигән сүзләр колакка чалына тора.* М.Хәсәнов

**Чалынып алу** *к.* **чалынып китү**. *Миңа берзаман эчтә бер шәүлә чалынып алды.* З.Хөснияр. *--- алдагы елда гыйнвар аенда булачак СССР Югары Советының тәүге сессиясе хакындагы сүзләр чалынып ала.* Ф.Сафин

**Чалынып китү** Кинәт чалыну. *Владивостокны алганда урам атышларында Кәримнең күзенә ак офицер Зыя Апанаев чалынып киткән булса да гаҗәпмени?* А.Тимергалин. *Кинәт бер мизгелдә автомобильнең номеры күзгә чалынып китте: 666!* А.Гыймадиев

**Чалынып тору** Даими яки әледәнәле чалыну. *Изге эш кенә ул күзгә чалынып тормый, чалынса да, тиз онытыла.* М.Юныс

**Чалынып үтү** Нәрсәдер уңаеннан тиз арада чалыну. *Ярлы лакей сыман ярым бөгелеп баскан Никита Кудрявцев, Александр Сергеев күзенә чалынып үтте.* В.Имамов. *Ак халатлы кешеләрне абайлады, карашына алардан читтәрәк басып торган, озын ак күлмәк кигән ниндидер бабай чалынып үтте.* А.Әхмәтгалиева

**ЧАЛЫШ** *с.* **1.** 1) Кыек, авыш, кыегайган, кыйшайган. *Шәһәрдән читтә бу мәдрәсәдән 5 – 6 чакрымлык йирдә булган зияратка шундый кышкы суык буранда чалыш ката, нәзек бишмәт, башка җылысы тимәгән чалма белән бару – бу җиңел эш түгел, инде Ходай үзе ярдәм бирсен!* Г.Ибраһимов

2) Атлаганда аяк очлары эчкә карап торган. *Чалыш аяк, кәкре борын – Тукран кызы Зәкия, дигән такмак иде ул.* А.Шамов

3) Күз каралары төрле якка караган; кылый. *Син миңа чалыш күзеңне акайтып карама – курыкмыйм мин синнән!* З.Зәйнуллин

4) *күч.* Үзгәртеп, бозып күрсәтә торган. *Барлык оешмаларның хезмәтләрен үз аршыны белән үлчәргә гадәтләнгән прораб Җайтабаровның авыру зиһене вакыйгаларны чалыш көзгедәй бозып күрсәтә иде.* Г.Афзал. *Ниндидер чалыш көзге бу, башы-аягы алышынган тормыш...* Г.Гыйльманов

**2.** *рәв. мәгъ.* Кыек, авыш итеп, кыегайтып. *Юк икән, баштан ук туры атлап китмәсәң, аяк гел чалыш атлый икән!* А.Гыйләҗев. *Миңа үзегез күреп ышангансыздыр: күзегезгә чалындымы берәр чалыш төягән төзүче?* А.Хәлим

◊ **Чалыш килү** Эшкә берәр комачаулык чыгу, эш кирегә китү

**ЧАЛЫШАЙТУ** *ф.* 1) Чалыш итү, кыегайту. *Офицер чыраен сыткан сыман, авызын чалышайтып, мәкерле генә көлеп куйды ---.* М.Хәсәнов. *Сабадырев мыскыллап йөзен чалышайтты, бер кәлимә сүз дә кайтармыйча, Флора артыннан ашыкты.* З.Фәтхетдинов

2) Чалыш күренеш бирү, чалыш итеп күрсәтү. *Күзгем йөземне чалышайтамы?*

**Чалышайта бирү** *к.* **чалышайта төшү**. *Чәчен мәңге җыймаса да, иренеңә кишер төсендәге иннекне мул чәпәгән Наташа, олы авызын чалышайта биреп, Риммага дәште ---.* Кызыл таң

**Чалышайта төшү** Бераз чалышайту. *– Мин аны мичкә ыргыттым, – диде абзый, авызын бераз чалышайта төшеп.* А.Хәлим

**Чалышайтып бетерү** Тәмам чалышайту. *Ишекләр ачылса ябылмый, ябылса ачылмый дигәндәй – тәмам какшатып, чалышайтып бетергәннәр, ә яңалары юк.* А.Тимергалин

**Чалышайтып кую** Тиз генә чалышайту; чалышайган хәлгә китерү. *– Бөек вакыт? – дип, Гайнан калын иреннәрен чалышайтып куйды.* Ә.Мушинский

**Чалышайтып тору** Даими яки әледән-әле чалышайту; әле, хәзер чалышайту. *Чөнки күз төпләрендәге күгәргән эзләр әле узмаган, шешенгән йөзен ямьсезләп, авыр иреннәрен чалышайтып торалар.* Н.Акмал

**ЧАЛЫШАЮ** *ф.* Элекке хәленнән авышу, кыегаю; кыйшаю. *Алай-болай шифоньер чалышайса, шылтыратырсың.* З.Хәким

**Чалышаеп алу** Бик кыска вакытка чалышаю. *Иванов елмаерга тырышып карады, әмма елмаю урынына авызы гына чалышаеп алды, шуны үзе дә сизеп булса кирәк, тиз генә иелеп, кәрҗинен алды да Закирҗанга күрсәтте.* З.Хөснияр. *Чырае әледән-әле чалышаеп ала, сулышлары кайнар, тешләрен шыкырдата.* Ф.Баттал

**Чалышаеп бетү** Бик нык чалышаю; барысы да чалышаю. *Түбә калае тутыгып, күп җирдән тишкәләнгән, нигез өстендәге бүрәнәләре һәм тәрәзә аслары яртылаш черегән, ә болдыр баскычлары күптән череп, чалышаеп беткән иде.* Ә.Еники. *Козырёгы җәебеп, чалышаеп беткән киң читле фуражкасы белән маңгаен сөртә-сөртә: – Я, нишләргә уйлыйсыз? – диде.* А.Гыйләҗев

**Чалышаеп килү** Акрынлап чалышаю. *Әби әйткәнне аңларга тырышудан Фәрхунның авызы чалышаеп килде, бер күзе кысылды.* Р.Батулла

**Чалышаеп китү** Кинәт чалышаю. *Мин, ахрысы, кисәгрәк бордым, тарантас кинәт чалышаеп китте.* Ә.Еники. *Җавабында Бакыр батыр сул кулы белән Кузының йөзенә суккан, ул чалышаеп киткән.* Ф.Яхин

**Чалышаеп кую** Бер мәртәбә яки сирәк кенә чалышаю. *Ләкин, берничә минуттан кайтып кергәч, Фирданиясе танымый торды аны: --- күзләре коточкыч нәрсә күреп һушы алынгандай түгәрәкләнгән, һәр адымында аяклары чалышаеп куя, хәле дә беткән кебек.* Ф.Баттал

**Чалышаеп тору** Даими яки әледән-әле чалышаю; әле, хәзер чалыш булу яки чалыш күрену. *Хәер, бу урамдагы эрелеваклы агач йортлар барысы да диярлек я алга, я бер янтыкка таба чалышаеп торалар.* Ә.Еники. *Сөйләнә-сөйләнә, алар калтайган канатлары белән икесе ике якка чалышаеп торган урыс капка аша урамга чыктылар ---.* А.Хәлим

**Чалышая бару** Торган саен ныграк чалышаю

**Чалышая башлау** Чалышаерга тотыну. *Тимер баганалары чалышая башлаган иләмсез киң капкага җитәрәк тукталып калдым.* Җ.Рәхимов. *Көпчәкләрнең тимер кыршаулары купты, тырнаклары чалышая башлады.* Ә.Гаффар

**Чалышая төшү** Бераз чалышаю. *Әбинең кечерәк кенә түгәрәк ипи хәтле булып бөкресе дә чыккан инде, авызы да бераз чалышая төшкән, тешләре дә берән-сәрән генә калган.* Г.Бәширов. *Шактый искергән, чалышая да төшкән, түбәсенең бер башы такта, әчкәре башы – салам.* Ә.Еники

**ЧАЛЫШЛЫК** *и.* 1) Чалыш булу күренеше, кыеклык. *Җитмәсә, әле аның гаепләрен табып маташыр, бортларның чалышлыгына бармак төртеп күрсәтер иде.* А.Тимергалин

2) *күч.* Хата, дөрес булмаган нәрсә. *Иншалла, бу чалышлыклар безнең туганнан килгән кимчелекемез түгелдер.* Г.Исхакый

**ЧАЛЫШМА** *с.* 1) Кыек. *Аның --- болай да киң маңгаен тагын да биегәйтеп күрсәткән чигүсез түбәтәе, чалышма якалы җиләне, ялтырап торган кара читекләре – барысы-барысы якты нур чәчә.* Мәйдан

2) *мат.* Бер яссылыкта ятмаган һәм кисешми торган. *Чалышма турылар*

**ЧАЛЫ́Ш-МОЛЫШ** *с. к.* **чалыш-полыш**. *Клоуны әллә нишләр кылана: егылган була, авызын чалыш-молыш китерә, күзләрен акайта – барын да эшли, тик ыштанын гына салмый инде.* Р.Батулла. *Әмма багана башларында янган сукыр ут яктысында аларның чалыш-молыш атлап килүләреннән чамалап, колакны болай интектерүләренең төп сәбәбен төшенергә, аңларга була иде анысы.* Ф.Яхин

**ЧАЛЫ́Ш-ПОЛЫШ** *с. к.* **чалыш-чолыш**. *Сәбәхетдиннәр күпере турысыннан үтеп, казыклары кычыткannар эченнән чалыш-полыш тырпаеп торган читәннәр буйлап Җидегәнгә таба юл алдылар.* А.Хәлим

**ЧАЛЫШТЫРУ** *ф.* Берсен икенчесе өстенә кыеклап кую, аркылы кую. *Акрын гына уйнап торган оркестрга туктарга кушып, ике кулын чалыштырып күкрәгенә куйды.* И.Нәбиуллина

**ЧАЛЫШТЫРЫП** *рәв.* Аркылы-торкылы итеп; иңле-буйлы; кисештереп. *Чалыштырып чәчү*

**ЧАЛЫШУ** *ф. иск.* 1) Көрәшү, бил алышу

2) *күч.* Тырышу. *Тырышдык без бу журнал чөн чалышдык; Буның нәшренә шимди без алышдык.* Г.Тукай

**ЧАЛЫ́Ш-ЧОЛЫШ** *с.* **1.** Төрлесе төрлечә авышкан, кыегайган, тигезле-тигезсез булган, кыек-мыек. --- *өйләрнең эчләрен вак тартмаларга бүлгәләгәннәр, ишегалларын иске такталардан корыштырган чалыш-чолыш кетәкләр, утын сарайлары белән тутырганнар, ә кайбер йортларның капка-коймаларын сугыш елларында каерып-сүтеп, ягып бетергәннәр.* Ә.Еники

**2.** *рәв. мәгъ.* Тигезле-тигезсез итеп; кыек-мыек хәлдә. *Ул су буеннан әтигә таба, тар басмадан чыккандагы шикелле, әле бер ягына кыйшаеп, әле икенче ягына ава төшеп, чалыш-чолыш атлый башлаган иде, әти аны шундук куырып алды ---.* Г.Бәширов. *Күрәсең, рәте шул чама гына булгандыр: Эшләпә велосипедын чалыш-чолыш китереп, педален бик авырлык белән генә әйләндереп бара иде.* В.Нуруллин

**ЧАМ** *и. гар. иск.* Башлыча җылы якларда үсә торган, төзелешкә яраклы нарат; төрек (Ливан) нараты // Гомумән нарат. *Малай чагымда җәйге кичләрдә яр буенда чам агачы астында утырып, диңгездәге пароходларны күзәтәм, ә икенче ягымда – өскә чөелгән фонтаннар тавышы...* Казан утлары

**ЧАМА** *и.* 1) Исәп, якынча исәп. *Мондый тирәнлектә суның температурасы да җәен-кышын бер тирә, бер чама.* А.Хәсәнов. *Вакытның чамасы югала.* А.Нәҗми

2) Берәр эшнең гомуми хәле, торышы. *Зыя, атасына эшнең чамасын, кая барачагын белдерде дә, иптәше Госман белән аның фатирына таба юнәлде.*

Г.Ибраһимов. --- *Сәкинәнең һич тә кайтыр исәбе юк, һаман шулай бик нык хәтере калган килеш тора, йомшар чамасы күренми иде.* В.Нуруллин

3) Берәр нәрсәнең чиге, нормасы. *Күрәсең, дөньяда һәр нәрсәнең үз чамасы бар.* Г.Хөсәенов. *Дөресен әйткәндә, бу егетләрнең икесе дә, бераз гына түгел, җай чыкканда бөтенләй чаманы җуеп, мактанып җибәрергә яраталар.* А.Хәсәнов. *Монысы инде чамадан тыш мыскыллау иде.* В.Нуруллин

4) Берәр нәрсәнең якынча зурлыгы, күләме, урнашкан урыны. *Карт тагын бер мәртәбә казанның зурлыгын – чамасын карады ---.* Г.Ибраһимов

5) Берәр затның эш башкарырга сәләте, мөмкинлеге. *Үз хакыңны хаклап сүз әйтерлек чама юкмыни синдә?!* А.Гыйләҗев. *Билләһи, мин әйтәм, тагын ун ел гөрләтеп эшләрлек чама бар әле минем.* Р.Вәлиев

6) Берәр эшне башкарырлык хәл, мөмкинлек. *Бишмәт якасын күтәреп, җәйге фуражкасын батырып кисә дә, салкын җилнең бертуктаусыз чеметүенә чыдар чама юк.* А.Хәсәнов. *--- рас, ул аның белән тормыш итәргә ниятләгән икән, инде аны яклый алырлык чамасы булмагач, үзе дә Роза белән китеп барырга тиеш иде.* В.Нуруллин

7) Теләк, уй, ният. *Шул турыда Яңгырбайның байбичәсе Гөлбарчын белән бераз киңәш кылсаң, ике якның чамасын тартып карасаң, зарар итмәс!* Г.Ибраһимов. *Киткәннәренә инде ике айдан артык вакыт үтте, әмма кайтыр чамалары юк әле.* В.Нуруллин

◊ **Чаманы чамага китереп карау** Чагыштырып карау; уйлау, фаразлау. *Эш шартларының нинди икәнен, акчаның күпмерәк төшәсен белгәч, шуны күңелләрендә йөрткән уйлары белән чагыштырып, чаманы чамага китереп карыйлар да, өметле күренә, бәлкем оттырмабыз дип, үз юлларына китеп баралар.* Г.Ахунов. **Чаманы чамага тарту** Ничек тә тиешле таләпләргә якынайту, туры китерү. *– Аның нигезе билгесез инде, – дип йомшак кына карышты Зәбихов. – Чаманы чамага тартырбыз.* М.Хуҗин. **Чамасын тартып карау** Мөмкинлекләрен, хәлен, көчен исәпкә алу. *Хәзрәтләр арасында очраган бер шәкерттән сүз сорап, чамасын тартып карау бик гомуми бер гадәт булганга, Җәләшнең үтенүе, әлбәттә, җирдә калдырылмый.* Г.Ибраһимов. **Чама чамага туры килү** *к.* **чама чамадан ерак китмәү**. *Сезнең Латыйпов белән аралар ничек? Чама чамага туры киләме, әллә...* А.Гыйләҗев. *Ярар, ике метр дип алырбыз – чама чамага туры килер әле.* А.Тимергалин. **Чама чамадан ерак китмәү** Исәпләгәнчә, уйлаганча булу

**ЧАМАЛАП** *рәв.* Саклык белән, чама белән, чиген, нормасын белеп, кирәк, тиешле булган кадәр. *Шәмсегаян булганын чамалап, сак тота белә.* А.Гыйләҗев. *Башка чакны, авызымны киң ерып көлсәм, битемә җыерчыклар чыгар, дип чамалап кына елмаерга күнеккән ханым иреннәрен җыя алмый.* А.Хәсәнов

**ЧАМАЛА́У** *ф.* 1) Берәр әйбернең күләмен, микъдарын, авырлыгын, озынлыгын һ.б.ны якынча билгеләү. *Ул ташның авырлыгын чамалады да кизәнеп җибәрде.* А.Азимов

2) Якынча аңлау, белү, сизенү. *Алар Ихласны танымасалар да, тавышы көрлегеннән бу якның хуҗасы икәнен чамаладылар.* А.Гыйләҗев // Шулай булырга тиеш дип уйлау, уйлап карау, фаразлау. *Комарлы уеннардагы кебек, монда да уңай һәм уңайсыз (кулай һәм кулай булмаган) шансларны чамалап карарга --- кирәк.* А.Тимергалин

3) Исәпләү, ниятләү. *Син дә йорт кузгатырга чамалыйсың дип ишетәм.* А.Гыйләҗев

4) Игътибарлы булу, уяу, абай булу, уйлап эш итү. *Чамалап йөрегез инде, егетләр.* А.Гыйләҗев

5) Чара эзләү, әмәлен табарга тырышу, җаен табу. *Бар, тизрәк Усыга кайт та әтрәт алып килү җаен чамала!* В.Нуруллин

6) *сөйл.* Куллану, тоту. *Токмачың булса, әллә берәр тәлинкәсен чамалаган булыр идем.* А.Гыйләҗев

**Чамалап алу** Тиз арада чамалау. *Ә менә хәзер, әнисе дә аның хәлен чамалап алгач, аңа бик кыен, оят булып китте.* В.Нуруллин. *Фәләховның нинди аң, кайсы як тарафдары икәнен чамалап алу бик читен эш иде.* А.Хәлим

**Чамалап бару** Даими күзәтеп чамалау. *Бүгенге татар шигъриятен укып, аның үсеш тенденцияләрен белеп, чамалап баручылар шагыйрь Зиннур Мансуров иҗатының --- аерылып торуын төшенәләр булыр.* Б.Рәхимова

**Чамалап бетерү** Кирәк кадәрле, тиешле дәрәҗәдә чамалау. *Мөхәррирнең бары тик мөдир кушканны гына үтәгәнлеген чамалап бетермәгәнмен.* Г.Гомәр. *Хәлим үзенең кайда икәнен дә чамалап бетерми инде.* Г.Гыйльманов

**Чамалап җиткерү** *к.* **чамалап бетерү**. *Инде бер аягы белән чыгып бара, икенчесе бу якта калган, ә һаман да кая киткәнлеген чамалап җиткерми.* Ф.Яхин

**Чамалап йөрү** Мөмкин булыр дип санау, өметләнү. *Ата кеше улының күңеле кемгә төшкәнен алдан ук чамалап йөргән, ахрысы.* В.Нуруллин

**Чамалап калу** *Шулай да Өлфәт шигырьнең авторын һәм беренче юлын чамалап калды.* А.Тимергалин

**Чамалап килү** Күптәннән, электән чамалау. *Чынлап та, Фәнис күптән чамалап килә инде, төнгә каршы табигать кискен үзгәрә икән: кар карая, ә төн агара, яктыра...* Г.Гыйльманов

**Чамалап кую** Алдан чамалау. *Көндез үк бер җайлы урын чамалап куйган идем.* А.Гыйләҗев

**Чамалап тору** Әле, хәзер чамалау. *Яңгыр яварга чамалап тора.* Г.Ибраһимов. *Хәзер мин әйтәм: хәзрәт урынына кемнерәк чамалап торасыз?* А.Гыйләҗев

**Чамалый бару** *к.* **чамалап бару**. *Шуңа да ул бәйгене кызыксынып күзәтте, кемнең беләге нык, кемнең биле – чамалый барды.* З.Мурсиев

**Чамалый башлау** Чамаларга тотыну. *Төш күреп ятсам да, моның чынбарлык булмавын чамалый башладым кебек.* З.Мәхмүди. *Әфләтүневнең кем һәм нинди малай икәнен чамалый башладыгызмы инде?* А.Гыймадиев

**Чамалый тору** Әлегә чамалау. *Аннары мин сиңа элек тә, үзең өчен берәр йортны чамалый тор, дип әйткән идем инде.* В.Имамов

**Чамалый төшү** Бераз чамалау. *Кайсы дингә өстенлек биргәнен ул үзе дә чамалый төшәр иде.* Мәдәни җомга

**ЧАМАЛЫ** *рәв.* **1.** 1) Кирәк кадәр, билгеле бер таләпләргә туры килгән кадәр. *Чамалы гына булганда сентиментальносте да ярый ул, минемчә.* Г.Әпсәләмов

2) Чикле, җитәрлек түгел. *Хәзер алар кирәгенә тотылырга да чамалы калган иде.* Г.Ибраһимов. *Урысчасы да чамалы булгач, ул беразга югалып калды.* А.Хәлим. *Ә мактанчык кешедә зирәклек чамалырак була – моны барыбыз да беләбез...* Г.Гыйльманов

3) Аз, кечкенә. *Товарны чамалы гына калдыру. Багаж чамалы күренү*

**2.** *с. мәгъ.* 1) Билгеле бер күләм, микъдар, зурлык тирәсендәге, шул чамада булган. *Кеше башына унбишәр кадак чамалы әйбер тиде.* Г.Ибраһимов.

*Күләм-сыешлыклары белән чәй тәлинкәләре чамалы гына, ике тәлинкәсе ап-ак калайдан.* А.Хәсәнов

2) Түбән сыйфатлы, начар; сыйфаты тиешле дәрәҗәдә булмаган. *Котылуын котылды, әмма моның ни өчен шулай эшләгәнен бөтен авыл халкы белгән, һәм бу хәл Хәнәфинең болай да бик чамалы авторитетына тагын бер кат суккан иде.* В.Нуруллин. *Мөхәммәт ханның кәефе чамалы чак.* В.Имамов

**3.** *хәб. функ.* 1) Начар булу; кимчелекле. *Бик илтер идем, ләкин утын диген нәрсә үзебездә дә бик чамалы: салам-солам, куак-чыбык ягып кына көн күрәбез.* В.Нуруллин. *Акылы да, хәтере дә чамалы.* А.Гадел

2) Бердәй, тиң. *Үзе буйга минем чамалы – сигез-тугыздан артык булмас.* Г.Ибраһимов

**ЧАМАН** *с. диал.* Ялкау, үшән; чәмән (ат тур.). *Ат чаманына менгәнче, ике табаныңа ялын.* Мәкаль. *Бәет булды тәмамы, Яшь киленнең яманы – Мисле атның чаманы Эшләгәндә, тидия.* Г.Рәхим

**ЧАМАСЫ** *бәйл.* 1) Берәр нәрсәнең якынча зурлыгын, микъдарын, озынлыгын һ.б.ш.ны белдерә; тирәсендә, тирәсе. *Соңгы елларда безнең шәһәрдә ел саен егерме өч, егерме биш мең чамасы бала туып тора.* В.Имамов

2) Вакытны, вакытның дәвамлылыгын, яшьне якынча белдерә. *Профессор, зиһенен туплап, бер минут чамасы эндәшми торды, күзлеген бер урыннан алып икенче урынга куйды.* Г.Әпсәләмов. *Урманда шалаш корып, төн кунып, ике атналар чамасы шул печәнне саклыйдык.* А.Хәсәнов

3) Әйләнәсендә, тирәсендә. --- *бу чуалчык җинаятьнең җепләре Салахиев белән Ивановка да барып тоташа икән --- дигән гайбәтләр байтактан бирле телләрдә йөрсә дә, болар шул имеш-мимеш чамасыннан үтә алмаганнар иде.* Г.Ибраһимов

**ЧАМАСЫЗ** *с.* **1.** Чиктән ашкан, чамадан чыккан, бик күп; бик зур. *Рәшат, ымсынып, кыздан ягымлы сүз, теләктәшлек көтә иде, ә Луизаның күзләрендә чамасыз ачу гына кайный иде.* А.Гыйләҗев. *Мин исән чагында тарихта үземне булдыру түгел, анда милләтне булдыру өчен көрәштем һәм чамасыз кан һәм көч түктем.* А.Хәлим

**2.** *рәв. мәгъ.* Чамадан чыгып, кирәгеннән артык; чаманы белмичә. *Көн нык ук кичкә авышса да, чамасыз кыздыра, алҗыта.* А.Гыйләҗев

**3.** *кис. мәгъ.* Үтә, бик, искиткеч. *Шундый ягымлы, уңган ата-анадан нигә киребеткән, үҗәт, чамасыз шук балалар туа икән?* А.Гыйләҗев. *Алланың кодрәте чамасыз киң, аны бирәү дә белми.* А.Гадел

**ЧАМАСЫНДА** *бәйл. к.* **чамасы**. *Рөстәмнең исе китте: аның алдында урта яшьләр чамасында гаҗәп чибәр һәм сөйкемле хатын кулларын җәеп басып тора иде.* Г.Кутуй. *– Вакыт өйлә намазы чамасында бугай, – дип нәтиҗә ясады ул.* А.Хәлим

**ЧАМЧАРАК** *и. әрм.* Әрмән халкының күрәгә, йөзем, тут җимешләреннән пешерелә торган салкын ашы. *Чамчарак белән сыйлау*

**ЧАН** *и. кыт.* Агач яисә металлдан, кайчакта кирпечтән ясалган бик зур һәм тирән мичкә. *Складтан вагонеткаларга төяп китерелгән тиреләр юешләү чаннары тирәсендә өелеп чират көтәләр.* А.Алиш. *Үзәк чан янында махсус таска яшькелтрәк төстәге ярымсыек болгар сабыны салынган иде.* А.Тимергалин

**ЧАНА** *и.* 1) Ике табанга утыртылган, ат җигеп яисә трактор яки башка төрле ысул белән йөк ташу яки кешеләр йөртү өчен җайланма. *Җирән бия шактый көр булса да, чананы авыр тарта, уйсу урыннарда гына түгел, кашлакта да тирән кар ята.* А.Гыйләҗев. *«Әйе-е... йомыкый дип йөргән малаебыз безне утыз-кырык тапкыр уздырган лабаса», – дип телен шартлатты ул, электромоторлы чанага, автомат рәвештә тавыкларга бодай һәм су бирә торган җайланмага, бәрәңгене сортларга аеру машинасына һәм шуның ише бихисап механизмнарга карап.* А.Гыймадиев

2) Балаларны утыртып йөрү, таудан шуып уйнау яки кечерәк йөкләр тарту өчен ике табанлы җайланма. *Аны быел кыш таудан чана шуганда баганага бәрелеп сындырган иде ул.* А.Хәлим. *Менә балаларга тагын бер чана алдым.* А.Гыйләҗев

3) *к.* **карга сөяк**. *Гали мулла, казның чана сөяген кимергән килеш: «Шәһәрнең сезнең кебек акыллы кешеләре нәрсә уйлыйлар соң?» – диде.* Ш.Камал

4) *спорт.* Улак формасындагы махсус бормалы, бозлы трассада зур тизлек белән төшү өчен табанлы спорт инвентаре; боб. *Иванны инвалид иткән бобслей чаналары ярышында бәхетсезлек очраклары еш булып тора.* Шәһри Казан

◊ **Чана чукмары** Арттан калмый тагылып йөрүче кеше

**ЧАНАХ** *и. төрек* Төньяк Кавказда, Грузиядә сарык сөтеннән махсус савытларда тозлыкта тотып ясала торган сыр төре. – *Чанах, лори, мотал сырлары, толым рәвешендәге чечил, чабыр үләне һәм башка тәмләткечләр белән ясалган Ехегнадзор сырын бездә генә табарга була, – ди Арам.* Шәһри Казан

**ЧАНА́ХИ** *и. груз.* Сарык ите, бәрәңге, бадымҗан, помидор һәм төрле яшел үләннәр салып мичтә яисә газ мичендә балчык савытларда томалап пешерелә торган грузин халык ашы. *Кафега кереп, Кавказ үләннәреннән пешерелгән кайнар чәй, чанахи, шашлык ашап чыккач, бу манзараны бер фотосурәткә төшерик әле дисәк, тау башын томан каплаган.* Сөембикә

**ЧАНАЧА** *и.* Озын әйберләрне ташу, күчерү өчен, төп чанага тагыла торган кечкенә чана; *русчасы:* **подсанки**

**ЧАНА́-ЧАҢГЫ** *и. җый.* Чана һәм чаңгылар. *Миңнуллаларның үз авыллары тирәсе тип-тигез, рәхәтләнеп чана-чаңгы шуарлык бер генә тау да юк.* В.Нуруллин

**ЧАНАЧЫ** *и. сөйл.* 1) Чана ясаучы кеше, чана остасы. *Шулай дулаган да икенче – телсезрәк чаначыдан тегенең күз алдында кыйммәтрәк бәягә чана сатып алган.* М.Мәһдиев

2) *иск.* Забойдан күмер ташучы эшче. *Чубай, --- чананы күрсәтеп, шуңа чапкан күмерне төяп, чаначыларның, тартып, вагоннарга илтүләрен, үзенең Николай заманында крепларга асыла-асыла, елап, чана тартуларын сөйләп китте.* Һ.Такташ

3) *спорт* Чана спорты белән шөгыльләнүче спортчы. *Биатлончылар, хоккейчылар, фигуралы шуучылар, шорт-трекчылар, чаначылар һәм кёрлинг уенчылары әнә шундый карар кабул иткән.* Ватаным Татарстан

**ЧАНДЫР** *с.* Ябык, мускул тукымалары майсыз булган, какча. *Иң элек Толстый Назимовны уртачадан озынрак буйлы, чандыр гәүдәле, чандыр йөзле, киң калку маңгайлы, егерме биш-егерме җиде яшьләрдәге бер кеше алдына алып килде.* Г.Әпсәләмов. *Электән дә кечкенә һәм чандыр гәүдәле әнисе хәзер тәмам корышып, кибеп калган.* В.Имамов // Ябык гәүдәле. *Аннары килеп, син дә бит ул чакта хәзерге шикелле пешкән алмадай чибәр түгел, чандыр гына, оялчан гына бер кызчык идең.* В.Нуруллин

**ЧАНДЫРЛАНУ** *ф.* Ябыгу, чандырга әйләнү. *Түгәрәк гәүдәсе үсмер малайларныкы кебек кечерәйде, чандырланды.* Ф.Яруллин

**Чандырланып китү** Кинәт чандырлану. *Сиринә үзе белмәсә дә, колхоз эшенә йөри башлагач, бераз тартылып, чандырланып китте.* Ф.Яхин

**ЧАНДЫРЛЫК** *и.* Ябыклык, чандыр булу. *Йөзгә чандырлык чыккан, күзләр эчкә бата төшкән.* А.Расих. *Шул ук озынча ак бит, атасыныкы төсле калын кашлар, тынгысыз коңгырт күзләр, шул ук чандырлык, юкалык.* Н.Фәттах

**ЧАҢ** I *иярт.* Металлга металл бәрелеп алган тавышны белдерә. *Әллә белә, әллә белми, әллә җылый, әллә чыңлый: даң, даң, чаң!* Г. Бәширов

**ЧАҢ** II *и.* 1) Металлдан (бакыр яки аның эретмәсеннән) конус рәвешендә коеп ясалган, эчендә асылган теле, стенасына бәрелеп, яңгыравыклы тавыш чыгара торган зур кыңгырау. *Бәлки, чаңны поп кактырмый торгандыр, бәлки, үз белдеге белән пономарь кага торгандыр?..* Г.Бәширов. *Кизү торучы Мәдинә түти, каравыл өендәге тукмаклы сәгатьтән вакытны карап, сәгать саен каланчага күтәрелеп чаң суга.* Ә.Моталлапов

2) Сигнал бирү өчен кыңгырау урынына асылган тимер кисәге. *Эшкә чакырып, кырда чаң кактылар.* М.Җәлил

3) Шуларның тавышы. *Тоткыннарның йөрәген өшетә торган, нервларын өзелердәй итеп какшата, акылны томалый торган чаң!* И.Салахов. *Наиләнең зәһәр тавышы, Нәҗипнең колагында чиркәү чаңы гүләгән сыман, «бу-бу-бу!» ишетелеп торды.* А.Гыйләҗев

◊ **Чаң кагу** 1) Халыкның игътибарын җәлеп итү. *Бу хакта әйтү генә аз, бөтен авылга чаң кагарга кирәк.* Ф.Яруллин; 2) Барлык кешегә сөйләп йөрү, күпләргә җиткерү. *Иң нык уйландыра һәм чаң кага торган әйберләр – шушылар кебек.* А.Тимергалин. **Чаң сугу** *к.* **чаң кагу.** *Милициягә тапшырырдай эш килеп чыгармы анда, шәһәр җитәкчеләре каршында чаң сугардай булырмы – анысын күз күрер.* В.Имамов. *Җитмеш ел элгәре урманнарны тураклаганда чаң сугарга иде, Ләйлә!* Н.Гыйматдинова

**ЧАҢ** III *и. иск.* Тузан. *Чаңсыз чакта чаң куптарма.* Әйтем. *Җәяүле солдатлар әнә шул тузан-чаң болыты эчендә күмелеп бара.* С. Поварисов

**ЧАҢГЫ** I *и.* 1) Кешегә карда, кайчакта су өстендә хәрәкәтләнү өчен, алгы очлары бераз күтәрелеп торган тар яссы агач яисә пластик табан(нар). *Аучы Мозаффар абзый кылдан ясалган петляләрен рәтләде, капкынналарын җайлады, җилкәсенә ике көпшәле мылтыгын салды да яңа яуган кырпак кар битенә чаңгысы белән эз калдырып китте.* А.Алиш. *Без кайтып килгәндә, Низам бабайлар тавы чуп-чуар: малайлар-кызлар кайсы чана, кайсы чаңгы, кайберләре хәтта бәлеш табаларына утырып, чыр-чу килеп тау шуалар иде.* В.Нуруллин

2) Махсус транспорт, җайланмалар кар яисә су өстеннән хәрәкәтләнү өчен пластик яисә металл табан(нар). *Җәй катерга тагылып су чаңгысында йөрергә, кыш балыкчы кирәк-яраклары, каргизәр биреп торырга мөмкин.* З.Мурсиев. *Очкыч кызулап селкенә-селкенә барды да, бермәлне шул селкенүе бетеп куйды, димәк, чаңгылар җирдән аерылды.* З.Мурсиев

з) Карда шуу өчен ясалган яссы табаннардан гыйбарәт спорт инвентарендә төрлечә ярышудан (спринт, эстафета, скиатлон, тау чаңгысы һ.б.ш.дан) торган кышкы спорт төрләренең берсе. *Мәктәп елларында ук бөтен күңеле белән спортка гашыйк кыз училищеда уку елларында район, республика ярышларында катнаша, призлы урыннарны ала, чаңгы буенча республика чемпионы була.* Г.Мөхәммәтшин. *Алтынчы көнне медальләр тау чаңгысында гына уйнатылды.* Кызыл таң

**ЧАҢГЫ** II *и.* Өч яки дүрт кыллы уен коралы (хәзерге вакытта грузиннарда кулланыла); *русчасы:* **чанги**. *Чаңгы чиртү*

**ЧАҢГЫЛДА́У** *ф.* 1) Металлга металл көчле бәрелгәндә чыккан тавышларны белдерә. *Үзе чакы-чокы килер, семафорлар алдында абзардан чыккан нәсел айгырыннан яман тавыш белән акырып, туктаганда буферларын имансыз рәвештә бәргәләп, йөрәгеңне өшетерлек итеп чаңгылдар ---.* Казан утлары

2) Кайбер кошларның көчле әче тавыш белән кискен кычкыруын белдерә. *Йөрәгенә сыймаган шатлык, матурлыкка манчылган бу сөенеч, егет күкрәгеннән ярып чыгып, җыр булып баягы кыяларга бәрелгән, нур булып бөркетләр чаңгылдаган күккә ашкан ---.* Т.Гарипова

3) Артык кычкырып яки ачуланып ризасызлык белдереп сөйләү

**Чаңгылдап кую** Кинәт чаңгылдау. *Сирай абыйның исә казлар арасындагы ата каздай чаңгылдап куюлары бер кешегә ошап бетми.* Т.Нурмөхәммәтов

**ЧАҢГЫ́Л-ЧОҢГЫЛ** *иярт.* Металлга металл төрлечә бәрелгәндә барлыкка килгән төрле югарылыктагы тавышларны белдерә

**ЧАҢГЫРАК** *и.* 1) Тирмә каркасының иң югары өлешендә уыклар кидерү өчен тишекләре булган коршау формасындагы детале. *Чаңгырагы киртештән, Увыгы бар көмештән, Бусагасын бурлаткан, Кирәгәсен сырлаткан Утауга килде Идегәй.* Дастан. *Алдан, пар үркәчнең ике ягына йон арканнар белән урап бәйләнгән киез өй кормалары, кирәгәләр, киезләр, уклар, чаңгыраклар һәм башка йөкләрен акрын гына тирбәлдереп, дөяләр атлады.* И.Салахов

2) *иск.* Коршау; тугым. *Төңгер чаңгырагы*

**ЧАҢГЫРА́У** I *ф. к.* **чаңгылдау**. *Кызлар, гөрләшеп, Җиләк җыялар. Чалгы чаңгырый, Болын яңгырый.* Н.Думави

**ЧАҢГЫРА́У** II *с.* Чаңгылдый торган. *Чаңгырау торна биегән җирдә иген булмый.* Сынамыш

**ЧАҢГЫ-РО́ЛЛЕР** *и. спорт* Кечкенә тәгәрмәчләргә – роликларга утыртылган кыска чаңгылардан гыйбарәт спорт инвентаре. *Хәзер теләгәннәр шарлавыклы буаның бер башыннан икенчесенә кадәр, ягъни шәһәр күленнән Бигәшкә кадәр араны җәяүләп яки велосипедта, роликта, хәтта чаңгы-роллерларда үтә ала.* Әлмәт таңнары. *Республиканың иң көчле чаңгычы узышчылары чаңгы-роллерларда ярышта һәм кросста катнаштылар.* Ютазы таңы

**ЧАҢГЫ́-ЧАНА** *җый. и. к.* **чана-чаңгы**. *Дөрес, якты вакытта чаңгы-чана шуулар, бозда кәшәкә уйнаулар да бездән читтә калмый иде.* Р.Вәлиев

**ЧАҢГЫЧЫ** *и.* Чаңгы(да) шуучы. *Бу оста чаңгычының урман белән таныш булган кыю бер кыз икәнен күрү кыен түгел иде.* Г.Әпсәләмов. *Көчле чаңгычы походта зур табыш бит ул.* А.Хәсәнов // Чаңгы спорты белән шөгыльләнүче. *Ул тәрбияләгән чаңгычылар зона һәм республика ярышларында нәтиҗәле чыгыш ясыйлар.* Г.Мөхәммәтшин // Чаңгылы гаскәргә караган хәрби. *Безнең полктан тыш биредә тагын парашютчылар бригадасы, генерал Беловның гвардейский атлы корпусы һәм чаңгычылар отрядлары хәрәкәт итәләр.* Казан утлары

**ЧА́Ң ИТҮ** *ф.* Чаң сыман тавыш чыгару

**ЧАҢК** *иярт.* 1) Металлга метал бәрелеп алганда чыккан өзек тавышны белдерә

2) Бөркет һ.б.ш. кошлар бер тапкыр кычкырып куйганда ишетелгән кискен тавышны белдерә

**ЧА́Ң КАГУЧЫ** *и.* Чиркәүдә чаң кагу эшен башкаручы кеше; *русчасы:* **звонарь**. *Чиркәүнең чаң кагучысы, армиягә яңа алганнарны «изгеләштерү» өчен, кыңгыраулары янына менеп китә.* М.Глухов. *Чиркәү мәйданында --- чаң кагучылар өчен мастер-класс булачак.* Таң

**ЧА́ҢК ИТҮ** *ф.* Чаңк сыман тавыш чыгару. *Җиргә төшерү белән, кош күккә карап-карап торды, муенын сузып, чаңк итеп тавыш бирде, аннан йөгереп китте һәм һавага күтәрелде!* Ә.Әминев

**ЧАҢКУБЫЗ** *и. муз. тар. к.* **чаңчалгы**. *Алтын башлы чаңкубыз Кыз кулында чыңлыйдыр; Кыл кубызын чыңгытып, Елый биреп җырлыйдыр ---.* Идегәй. *Алан өстендә җыр авазлары сирәгәя төште: чаңкубызлар талды, курайчыларның тыны бетте.* Ф.Латыйфи

**ЧА́ҢК-ЧОҢК** *ияртм.* Металлга-металл төрле көч һәм төрле тизлек белән кабат-кабат бәрелгәндә чыккан тавышны белдерә. *Меңнәрчә кылыч кылычка бәреләә: чаңк-чоңк, чакы-чокы, чакы-чокы...* Р.Батулла

**ЧАҢКЫЛДА́У** *ф. к.* **чаңгылдау.** *Түбән оч алачыгында да без икәү чүкеч чаңкылдаганны тыңлап утырабыз.* Р.Батулла. *Ирәндек бөркете бүген һичкайчан булмаганча ачыргаланып чаңкылдый...* Т.Гарипова

**ЧАҢЧАЛГЫ** *и. муз. тар.* Төрки халыкларның бакыр асылмалары булган, сызып уйный торган хәрби музыка коралы. *Чаң-чалгылар чалдырып, Күн давылбаз дыңкытып, Дум-думбаклар ордырып, Туй-тамаша кылдырып, Каласына юнәлде.* Дастан

**ЧА́Ң-ЧАҢ** *ияртм.* 1) Чаң какканда, калай нәрсәләргә бәргәндә чыккан тавышны белдерә

2) Бөркет, кыр казлары, аккош кебек кошларның кычкырган тавышын белдерә

**ЧА́Ң-ЧАҢ ИТҮ** *ф.* Чаң-чаң сыман тавыш чыгару. *Чаң-чаң итә ирәндек бөркете.* Җыр

**ЧА́Ң-ЧАҢ КИЛҮ** *ф. к.* **чаң-чаң итү**

**ЧА́Ң-ЧОҢ** *ияртм.* Металлга металл яки башка әйбер бәрелүдән чыккан төрле югарылыктагы тавышны белдерә; чаң-чаң. *Чаң-чоң чалгы тапыйлар.* А.Хәсәнов. *Иртән чаң-чоң чалгы сугарлар...* З.Мурсиев

**ЧА́Ң-ЧОҢ ИТҮ** *ф.* Чаң-чоң сыман тавыш чыгару. *Су өстендәге басмада, бөтен инеш буйларын яңгыратып, кемдер керләр бәләкли, тимерче алачыгында чаң-чоң итеп чүкеч сугалар.* Г.Бәширов

**ЧА́Ң-ЧОҢ КИЛҮ** *ф. к.* **чаң-чоң итү**

**ЧАП** I *и. иск.* Халык арасындагы дан, исем

◊ **Чабы чыгу** Берәр кешенең яманаты, начар даны чыгу, яман сүз таралу. *Яхшы кызның даны чыгар, яман кызның чабы чыгар.* Мәкаль. **Чабы китү** *к.* **чабы чыгу**. *Васфибану гакылсыз кыз түгел, егет берлә йөрүнең зарарлы икәнен дә белә һәм андый чабы киткән кызның кадере юклыгын да белә иде.* Г.Исхакый

**ЧАП** II *ияртм.* Яңакка, суга уч белән сукканда, пычракка, суга кинәт басканда, авыр әйбер килеп төшкәндә чыккан тавышны белдерә. *Мин коры җир дип бассам, ул өеп куйган пычрак икән. Чап! пычракның уртасына.* Г.Камал

**ЧАП-** *кис.* Кайбер сыйфатлар белән килеп, шуларның артыклык дәрәҗәсен ясый. *Ватык шешәләр, буш консерва савытлары арасында куак төбендә чалкан ятып йоклаган чап-чандыр хатыннан башка нәрсә күренмәде.* Р.Батулла. *Чеп-чибәр, чап-чая кыз.* Т.Миңнуллин

**ЧАПАК** *с. диал.* 1) Тапкыр, зирәк; тере. *Чапак бала*

2) Үткен, чәнечкеле (тел тур.). *Усал, чапак телле егет-җилән, аның исемен ялгыш ишеткәнгә салышып, бозып: «Нихәл, Кисмәк улы?» – дип үрти, үчекли, ирештерә үзен.* И.Диндаров

**ЧАПАЛАК** *и. сөйл.* 1) Уч төбе белән яңакка сугу. *Чапалак бирү*

2) Сапка утыртылган резиннан гыйбарәт чебен үтерү коралы; шапалак. *--- клеёнка кисәге бар иде, аннан укытучы Рәүф абый чебен үтерергә чапалак ясаган икән.* Н.Сабиров. *Алар чапалак тотып озынборын куып йөри.* Р.Рахман

3) Артсыз җиңел аяк киеме. *– Менә бүлнистән генә чыктым әле, – дип, ул аягындагы «Б» хәрефе сугылган --- чапалакларына ымлады.* Г.Гомәр

4) *күч.* Берәр кешегә карата ясалган бик зур начарлык

**ЧАПАЛАНУ** *ф. диал.* Чәбәләнү. *– Ул кадәр үк чапаланма син! – диде Рәдиф, минем кыза башлавыма бер дә алай исе китмичә.* В.Нуруллин

**ЧАПАН** *и. гар.* Мөселманнарның җилбәгәй җибәреп йөртелә торган халат шикелле озын чабулы юка өс киеме. *Өряңа чапаннар унбиш тиен көмеш тора.* А.Гыйләҗев. *Өстенә көмеш җепләр белән бизәлгән бәрхет чапан, асылташлар тагылган ап-ак чалма киеп алган тархан кунакларны якты йөз һәм ихтирам күрсәтеп сәламләргә ашыкты ---.* В.Имамов

**ЧАПАНЛЫК** *и.* **1.** Чапан тегәр өчен билгеләнгән тукыма. *Түшәк тышлыгы белән Һаҗәргә дигән чапанлыкны калдырып торырбызмы?* С.Шәрипов. *Мина иң яхшы яшел ефәктән бер чапанлык бир.* Җ.Ильясов

**2.** *с. мәгъ.* Чапан тегү өчен билгеләнгән; шуңа җитәрлек. *Чапанлык тукыма. Чапанлык акча*

**ЧАПА́Н-ЧАЛМА** *җый. и. к.* **чалма-чапан**. *Батырҗан дәрвиш булып киенгән, сакал-мыек ябыштырган, чапан-чалма кигән.* А.Гадел

**ЧА́П ИТҮ** *ф.* 1) Яңакка, суга уч белән сукканда, пычракка, суга кинәт басканда, авыр әйбер килеп төшкәндә һ.б.ш. очракларда яңгыравык тавыш чыгу. *Мәрфуганың агач табагына табельщик өч чүмеч өйрә сала, хисапчы, яшел эмальле зур табактан өч кисәк ит алып, чап итеп, Мәрфуга табагына ыргыта.* М.Мәһдиев

2) *күч.* Каты итеп сугу. *Икенче вакыт рота командирына да ул: – Есть, товарищ капитан, ач артыңны, чап итәм! – дип җибәрде.* Р.Кәрами. *Капитан, капитан, авызыңа чап итәм...* Л.Лерон

**ЧАПКЫ** *и.* 1) Ит яки кәбестә ваклау өчен, сапка аркылы беркетелгән ярымтүгәрәк киң генә пычактан гыйбарәт корал. *Кәбестәне чапкы белән ваклау*

2) Ит, кәбестә тапау өчен агач тагарак. *Сугышка кадәр бу чапкыда сарык ите турала иде...* М.Мәһдиев

**ЧАПКЫЛА́У** *ф.* Чапкы белән чабып ваклау

**ЧАПКЫН** *и.* **1.** 1) Ашыгыч хәбәр, йомыш белән җибәрелгән кеше. *Глеб юллаган гаярь чапкын килде ---.* В.Имамов. *Шулкадәр ышанычсыз яугирне дошман өненә чапкын итеп җибәрәләрме?* З.Мәхмүди

2) Йөгерек ат. *Юк, дип башын чайкап уйлануында булды Бәйрәмхан, инде аңа көчем җитмәячәк, аннары, әти әйткәндәй, ишәкне колагын кисеп кенә чапкын итеп булмый.* М.Хуҗин

3) Баскын, талау сугышы. *Алмыш ханның иң яхшы атлары шушында. Чапкын өчен, яу өчен симертелә.* Н.Фәттах

**2.** *с. мәгъ.* 1) Йөгерек. *Иске ысул – чапкын атлар белән, бер-ике сәгать*

*эчендә бөтен Идел буена үлү хәбәре таратылган ---.* Г.Исхакый. *Чапкын атларның биле чыдамый шул инде хәзер безгә.* М.Маликова

2) *күч.* Ашкынып торган. *Тик нишләтим чапкын йөрәгемне? – Уйлап тормый, һаман ашыга.* Р.Зәкуан

3) *күч.* Тиз үтә торган. *Бу чапкын елларга Нинди җыр җырларга, – Моң белән йөрәкләр яралы.* Г.Афзал

**ЧАПКЫР** *с.* **1.** 1) Яхшы чаба торган, йөгерек. *Тайтулак юлга чыкмавына үпкәләде бугай, йомшак, елак кешнәде, чапкыр атның әлегә камытыңгырчакны тоеп караганы юк, аңа чуклы ияр килешә, ияргә күнекте ул.* М.Хуҗин. *Бәйгеләрдә чапкыр аты белән алда килгәне өчемне, әллә орышларда дошманына кылыч белән хәтәр чапканы өченме – билгесез.* Р.Батулла

2) *күч.* Тиз үтә торган, ашыгыч. *Чапкыр тормыш*

**2.** *и. мәгъ.* Йөгерек ат. *Түземсезләнеп авызлык чәйнәп ярсыган яшь чапкырлар, тезгеннәре бушауга, үзләре кебек үк яшь җайдакларны бер ыргымда дошман сафлары арасына алып кереп тә киттеләр.* Ф.Латыйфи

**ЧАПКЫЧ** *и.* **1.** Печән, иген һ.б.ш.ны чабу машинасы. *Колхозга, Бәләбәйнең үзенә тикле барып, атларга җигеп йөри торган ике төрле чапкыч кайтардылар.* В.Имамов. *Соң, тимер сабаным, чапкычым бар.* З.Мурсиев // Уру-чабу машиналарының чапкыч механизмы. *Өчәүләшеп басуга барып җитсәләр, комбайн бодай ура, ә ул тагын ике тапкыр сикерсә – ялгыз көнбагыш чапкыч авызына эләгә иде.* Н.Гыйматдинова

**2.** *с. мәгъ.* Чабу җайланмасы булган; чабу өчен хезмәт итә торган. *Механизаторлар комбайннарын, чапкыч җайланмаларын көйләп куйганнар.* М.Зарипов

**ЧАПРАК** *и.* Ияр астына салына торган киез һ.б.ш. калын япма; *русчасы:* **попона**. *Иярең астына чапрак салырга оныткансың...* М.Хуҗин

**ЧАПРЫШ** *рәв.* **1.** 1) Чалыш итеп, кыеклап. *Чапрыш атлау*

2) Начар, яхшы түгел. *Чапрыш эшләү*

**2.** *с. мәгъ.* Начар булган; чалыш, кыек. *Муртайган такта ярыкларыннан саркып кергән чапрыш кояш нурлары гына, тыгыз караңгылыкны телеп алып, яктылык тамчыларын чәчрәтә.* Р.Зәйдулла

**ЧАПТАР** *с. монг.* **1.** 1) Җирән яки көрән гәүдәле, озын ялы һәм койрыгы аксыл, чал, аксыл сары булган (ат төсе тур); *русчасы:* **игреневый**. *Минем чаптар алашаны, шәт, онытмагансыңдыр, ә?* А.Гыйләҗев. *Әтиеңә чаптар җурга алып бирермен, Ачуланса, җырак җуллар күрсәтермен.* Г.Макаров

2) *ялг.* Тиз чаба торган, чапкыр. *Җил дә куып тота алмаслык чаптар атка атланган егет урлап китсен әле үзеңне, уен эшмени!..* М.Хәсәнов

**2.** *и. мәгъ.* Шундый төстәге ат. *Сөю атлы чая Ак яллы чаптарың Аранда күптәннән, Күптәннән – яралы.* Г.Морат

**ЧАПТЫРДАТУ** *ф. к.* **чапырдату**. *Рафис артыннан баручы Рәкыйп, бишалты мәртәбә чаптырдатып атлаганнан соң, уң кулындагы тал чыбыгы белән җирне ярыр сыман кизәнеп ала.* Р.Рахман

**ЧАПТЫРДА́У** *ф. к.* **чапырдау**. *Савымчы кызлар, халатларын башларыннан бөркәнеп, сукмак буйлап чаптырдап йөгереп үттеләр.* А.Вергазов

**ЧАПТЫРУ** I *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **чабу** II. *Ат чаптырып, адәм көрәштереп, әллә ничаклы бүләкләр өләштеләр.* Г.Ибраһимов. *Матаен туп-туры сезгә чаптыра бит.* А.Гыйләҗев

2) Атны куалап тизләтү. *Атлар безне килгән юлыбыздан кирегә – Иделгә таба чаптырып алып киттеләр.* Г.Рәхим. *Кәҗә башы урамыннан, тегермән ягыннан, кушаяклап атын чаптырып, берәү килә иде.* А.Гыйләҗев

3) Бик тиз хәрәкәт итү; бик тиз бару. *Бүген минем гел чабасым, чаптырасым гына килә, атлап йөрүне бөтенләй оныттым.* Г.Ибраһимов

**Чаптыра башлау** Чаптырырга тотыну. *Алар, атларына атланып, эшлекле төстә дәррәү кузгалдылар һәм, кышлакны чыкканчы ук, камчыларын болгый-болгый юртакларын чаптыра башлап, тиздән тузан болыты эчендә күздән югалдылар.* Т.Әйди. *Дөрес, әүвәл – бер, соңрак ике-өч чакрым арага җан-фәрман чаптыра башлагач, Моrикан кинәт кенә кырысланып, җитдиләнеп китте.* В.Имамов

**Чаптыра бирү** Бернигә карамый чаптыру. *Тит боланнарны шул ук тизлек белән чаптыра биреп, озын колгасы белән әле уңга, әле сулга таба юл күрсәтә-күрсәтә, аларны куаклыклар арасыннан уздырды.* Н.Ихсанов. *Качып баручылар, ат өстендә килеш кенә, җиңелчә итеп фарыз вә сөннәтне үтәделәр дә әле сүнеп бетмәгән Казык йолдызына таба төбәп чаптыра бирделәр.* Ф.Яхин

**Чаптыра тору** Әлегә чаптыру. *Шаяртып тагын да өстәде: – «Җигүли» җигүле атыбыз чаптыра торсын!* Ф.Яхин

**Чаптыра төшү** Тагын да чаптыру. *Берничә минутлар шулай баргач, абый миңа: – Атны чаптыра төш! – диде.* Ф.Әмирхан

**Чаптырып алу** Бераз чаптыру. *Ерак юлга чыккач, атка бер минут та йомшаклык күрсәтергә ярамый. Кирәк чакта йөгерт. Чаптырып та ал.* С.Поварисов

**Чаптырып китү** Кисәк чаптыра башлау. *Мәнә ул арканны кисәк кенә тартып куйган, өске дөньядагы күл читендә басып торган ат, хуҗасын тыңлап, чаптырып та киткән.* Г.Гыйльманов. *Инде пар атка тулы куәт биреп, чаптырып китәм дип торганда...* С.Поварисов

**Чаптырып тору** Даими, кат-кат чаптыру. *Өлкән сыйныфтагылар бала-чаганы кибеткә дә, башка кирәк-яракка да чаптырып кына тордылар.* З.Мәхмүди

**ЧАПТЫРУ** II *ф.* Тума булдыру өчен, хайваннарны аталандыру, каплату. *Башкортка илтеп, алмачуар айгырдан чаптырырбыз да киләсе җәйгә бер дә җикмәбез.* Г.Ибраһимов. *Өч пот солы биреп, зур айгырдан чаптырып, яхшы колын алырмын дигән идем бит...* Т.Гыйззәт

**ЧАПТЫРУ** III *ф.* Көчле агым белән агу, ургылу; зур басым астында берәр төрле сыеклык сиптерү, агызу. *Абыйны да күрермен, шул уңайдан туган авылга кереп, кардәш-ыруның хәлен белеп, үзебезнең чаптырып ага торган чишмә суыннан кайнаган чәйне дә эчәрмен, мәйтәм.* Ф.Хөсни. *Көпшә [ярага] керүгә үк, сыеклык чаптырып бәреп чыкты.* Р.Батулла

**Чаптыра башлау** Чаптырырга тотыну

**Чаптырып җибәрү** Кинәт чаптыру. *– И җаным, и җаным, и җа-ны-ым! – дип өзгәләнә бабакаем. Шактый шулай өтәләнгәннән соң, чаптырып җибәргән тавыш ишетелде ---.* Т.Нәҗмиев

**Чаптырып тору** Әле, хәзер чаптыру; даими, әледән-әле чаптыру

**ЧАПТЫ́Р-ЧОПТЫР** *иярт.* Батгаклыктан, сулы урыннан барганда чыккан тавышны белдерә. *--- юл өстендә хасил булган бихисап күп боз күлчекләр язы. Шыгыр-шыгыр кар, четер-четер боз һәм чаптыр-чоптыр су!* Л.Ибраһимова

**ЧАПТЫ́Р-ЧОПТЫР ИТҮ** *ф.* Чаптыр-чоптыр килгән тавыш чыгару

**ЧА́ПТЫР-ЧОПТЫР КИЛҮ** *ф. к.* **чаптыр-чоптыр итү**. *Габделәхәт, атлап барган уңаена, бу сай инеш аркылы чаптыр-чоптыр килеп чыгып та китте.* Т.Нурмөхәммәтов

**ЧАПТЫРЫП** *рәв.* Бик тиз, җитез генә. *Алайса, Айрат, син тиз генә пилорамга чаптырып барып кил.* З.Мурсиев

**ЧАПЧАК** *и. диал.* Зур кисмәк. *Болар батманнарын, мичкә, чапчакларын, комганнарын, ашыгып-ашыгып, су белән тутырырга тотыналар.* Г.Ибраһимов. *Эх, урларга яраса, әллә кайчан безнең чапчакка су ташый торган кыз иде бит ул!* Т.Миңнуллин

**ЧАПЧАКЧЫ** *и.* Чапчак ясаучы, кисмәкче

**ЧА́П-ЧАП** *иярт.* Мунчада чабынганда, яланаяк ташка, сулы җиргә басып барганда, ялан тәнгә кул, сыгылмалы нәрсәләр белән берничә кат суккан-да чыккан тавышны белдерә. *Буаның бу ягыннан ук чап-чап чабынганы ишетелә иде.* Г.Исхакый. *Җир баласы идем, чапчап басып Яланаяк йөгереп йөргәндә, Җиргә якын, туфракка үз идем, Салмак атлап сабан сөргәндә.* Ш.Галиев

**ЧА́П-ЧАП ИТҮ** *ф.* 1) Чап-чап килгән тавыш чыгару. *Тугызак әбинең сизгер колагына су өстендә чап-чап иткән бер тавыш ишетелде.* Ф.Вәлиев

2) Мунчада чабындыру. *Кычыткан өзеп алып, Мунчада чап-чап иткән.* И.Юзеев

**ЧА́П-ЧАП КИЛҮ** *ф. к.* **чап-чап итү** (*1 мәгъ.*). *Әхсән, өчәр-дүртәр басманы берьюлы атлап, аска томырылды, ялан аяклар ташта чап-чап килделәр.* М.Маликова. *Лаштыр-лоштыр, чапчоп килә, Бераз туктап тора да.* Фидаил

**ЧА́П-ЧОП** *иярт.* Чапылдатып ашаганда, яланаяк каты өслектән яисә артсыз аяк киеме белән йөргәндә, су ярларга бәрелгәндә, үбешкәндә һ.б.ш. очракларда чыккан тавышны белдерә. *Җилле көннәрдә ул су ярларына чап-чоп бәрелеп утыра, су өсләрендә төнбоек, яр кырыйларында серле, куркыныч камышлыклар…* М.Мәһдиев. *Ашап туймаган бурзай төсле, өстәл янында иреннәреңне ялама, авызыңны чап-чоп чапылдатма.* А.Хәсәнов

**ЧА́П-ЧОП ИТҮ** *ф.* Чап-чоп килгән тавыш чыгару. --- *шактый урыннарда агач юл өстенә дә нindидер яшькелт күлдәвекләр чыгып тора. Солдатлар, чап-чоп итеп, аларның күзләренә басып узалар.* Казан утлары

**ЧА́П-ЧОП КИЛҮ** *ф. к.* **чап-чоп итү**. *Аларның зур тәгәрмәчләре, чапчоп килеп, каен миллек белән чабынгандагы шикелле, суны чәбәкләп баралар.* Ә.Маликов

**ЧАПЫЛДАП** *рәв.* Нык итеп, ябыштырып куйган кебек. *Муллаларга һәр сүз, гайбәт чапылдап ябышып бара.* Безнең гәҗит

**ЧАПЫЛДАТУ** *ф.* 1) Иреннәрне, аңкауны суырып, авызны кинәт ачыпябып яңгыравык тавыш чыгару. *Чапылдатмый ашасаң, тәме, ләззәте булмый аның.* К.Тинчурин. *Ә Матильда килештерде: күзләрен йомып, шул өч тамчы нәрсәне төймәдәй борыны тирәсендә йөртеп иснәгән булды, алсу телен тигезеп, иреннәрен чапылдатты, ах-ух килде.* К.Кара

2) Суга уч белән сугып, берәр әйбер бәреп, судан барып яки учка учны сугып яңгыравык тавыш чыгару. *Ул, ялан тәпиләре белән суны чапылдатып, иң кырыйдан атлый.* Г.Әпсәләмов. *Ошбу кит балыклары койрыкларын чапылдатканда, диңгездә зилзилә давылы куба, җирләр тетри, күкләр селкенә, дип әйтә голәмалар.* Г.Афзал

**Чапылдата башлау** Чапылдатырга тотыну. *Башта бала һични аңламый йөзен чытты, аннары авызын мәзәк итеп чапылдата башлады.* М.Хәбибуллин. *Башын калкытуга, капланган көймәгә тотынып, аякларын алмаш-тилмәш чапылдата башлады.* И.Сирматов

**Чапылдата бирү** Бернигә карамый чапылдату

**Чапылдатып алу** Бер-ике тапкыр, беркавым чапылдату. *Мәрьям, өне алынырлык сүз ишеткән сыман, кулларын чапылдатып алды.* М.Хәсәнов. *Шәүкәт, сабый бала сыман, иренен чапылдатып алды.* Р.Бәшәр

**Чапылдатып кую** Көтмәгәндә чапылдату; әллә нигә бер, бер тапкыр чапылдатып алу. *Боларны сөйләгәндә, Салих авызларын чапылдатып куя, әллә ниткән безгә аңлашылып җитмәгән ымлыклар чыгара.* Н.Әхмәдиев. *Мыгырдау белән ыңгырашу арасында булган тавышын чыгарып, Изаел, ике кулын да яңагы астына тыгып, авызын чапылдатып куя.* Р.Гаязетдин

**Чапылдатып тору** Әледән-әле чапылдату; әле, хәзер чапылдату. *[Габдулла] Шактый мәлне сүзләр оештыра алмый авызын чапылдатып торды.* А.Вергазов

**ЧАПЫЛДА́У** *ф.* 1) Телне аңкауга тидереп алганда, берәр нәрсә суырганда яңгыравык аваз чыгу. --- *биек, якты өй эчендә берьюлы меңләгән авызлар чапылдады, итләр чәйнәлде, алтын, көмеш табакларга тиеп, сөякләр, пычаклар, кашыклар шакылдады.* Н.Фәттах

2) Су ярга, җиргә, башка нәрсәгә бәрелеп яки суга сикерүдән, җиңелчәрәк тиеп китүдән яңгыравык аваз чыгу. *Аяклары астында йомшак мүк тибрәнде, кайчак су чапылдады.* Г.Әпсәләмов. *Камыллар эченнән нәрсәдер чапылдап суга сикерде дә уртага таба йөзеп китте.* Ф.Садриев

3) Су тамчысы яки юеш әйбер каты өслеккә төшеп, яңгыравык тавыш чыгу. *Шундый тын, хәтта бакча түрендә берничә баш умарта оясының гөжләве белән юеш чиләктән тамган эре тамчыларның чапылдап төшүе генә кайдадыр аста – кое тирәнлегеннән аермачык булып ишетелә иде.* М.Хәсәнов. *Юеш чалбарым белән, чапылдап, вак ташлар өстенә тезләндем.* Ф.Шәфигуллин

4) Балта белән чи агачны чапканда, юнганда яңгыравык тавыш чыгу. *Тарих мең дә җиде йөз дә фәләненче елларда урман арасында моңача кеше заты аяк басмаган аланда эш кызды: пычкылар чыңлады, балталар чапылдады.* З.Мурсиев

**Чапылдый башлау** Чапылдарга тотыну. *Сутлы балчык измәсенә су саласың-саласың, ул аны үзенә сеңдерә, эчә генә, эчеп туйгач, чапылдый башлый.* Р.Мирхәйдәров. *Атлый торгач, аяк астымда су чапылдый башлады.* Бөгелмә авазы

**Чапылдый бирү** Бернигә карамый чапылдау

**Чапылдап алу** Бер тапкыр чапылдау; бераз чапылдау. *Һични күренми, һични селкенми, су салкыны да сизелми, бары ишкәкләрнең тигез-салмак чапылдап алуы гына ишетелә иде.* Ә.Еники. *Тоныкына диңгез шаулавы ишетелә, дулкыннарның ярга ишелеп килүе һәм, бер кат чапылдап алганнан соң, тынычланып кире тәгәрәве тәнеңдәге айлар буе җыйналган бөтен киеренкелекне юып җибәрә.* Т.Әйди

**Чапылдап китү** Кинәт чапылдау

**Чапылдап кую** Көтмәгәндә яисә бер-ике тапкыр чапылдау

**Чапылдап тору** Әледән-әле яки туктаусыз чапылдау, әле, хәзер чапылдау.

*Аяк астында окоп төбендәге су һәрчак чапылдап тора.* З.Зәйнуллин

**Чапылдап яту** *сөйл. к.* **чапылдап тору**. *Соң килсәк тә, Мәдинә белән Разил түзмәде, сөлгеләрен иңнәренә салып, асфальт юлның аргы ягында гына чапылдап яткан диңгезгә су керергә йөгерделәр.* Т.Әйди

**ЧАПЫЛТ** *иярт.* Суга яки пычракка бер мәртәбә кисәк берәр нәрсә белән сукканда яки нәрсәдер төшкәндә чыккан өзек тавышны белдерә. *Чапылт... Нидер суга төште*

**ЧАПЫ́ЛТ-ЧОПЫЛТ** *иярт.* Суга берәр нәрсә төшеп торганда, пычрактан барганда һ.б.ш. вакытта барлыкка килгән өзек-өзек яки кабатлаулы тавышны белдерә. *Котырынган суга яңадан таш, чыбык-чабык, ком чапылт-чопылт сикерә башлый иде.* И.Гази

**ЧАПЫ́ЛТ-ЧОПЫЛТ ИТҮ** *ф.* Чапылт-чопылт килгән тавышлар чыгару

**ЧАПЫ́ЛТ-ЧОПЫЛТ КИЛҮ** *ф. к.* **чапылт-чопылт итү**

**ЧАПЫ́Л-ЧОПЫЛ** *иярт.* Бертуктаусыз чапылдау тавышын белдерә

**ЧАПЫ́Л-ЧОПЫЛ ИТҮ** *ф.* Чапыл-чопыл килгән тавыш чыгару

**ЧАПЫ́Л-ЧОПЫЛ КИЛҮ** *ф. к.* **чапыл-чопыл итү**. *Кунаклар, табакларга куллары белән кереп, ит кисәкләрен теләгәнчә сайлый-сайлый һәм берберсен согындыра-согындыра, чапыл-чопыл килделәр.* И.Туктар

**ЧАПЫРДАУ** *ф.* Баткактан, судан, пычрактан барганда, каты яки сулы өслеккә югарыдан су агып төшкәндә һ.б. кайбер эш-хәрәкәт башкарганда барлыкка килгән тавышны белдерә. *Егетләрнең үз өлешен алган һәркайсы башкаларны көтмичә үк ашарга ябышты – Чулман суында чапырдап, карыннары бик нык ачкан иде.* К.Кәримов. *Аның кулында булган нindидер әйбердән идәнгә чапырдап су ага иде.* Безнең гәҗит

**Чапырдап алу** Бераз чапырдау

**Чапырдап кую** Кинәт чапырдау; бер тапкыр чапырдау. *Почмактагы чиләктә су чапырдап куйды.* З.Хөснияр

**Чапырдый башлау** Чапырдарга тотыну

**ЧАПЫ́Р-ЧОПЫР** *иярт.* Баткак ерып, су җыелган урыннан барганда, өстән су акканда чыккан тавышны белдерә. *Пехота пычракта да чапыр-чопыр атлый бирә, ә бездә туплар.* З.Зәйнуллин. *Авылның тиле Әптерие, урам уртасына чыгып басып, шәрран ярып бер кычкырды да, яланаяк чапыр-чопыр пычрак ера-ера, елгага йөгерде.* З.Хөснияр. *Өс-башымнан чапыр-чопыр су аккан хәлдә, комлы ярга бассам, бөдрә таллар артыннан берәү кычкыра ---.* Н.Гыйматдинова

**ЧАПЫ́Р-ЧОПЫР ИТҮ** *ф.* Чапыр-чопыр килгән тавыш чыгару. *Аяк асты чапыр-чопыр итә*

**ЧАПЫ́Р-ЧОПЫР КИЛҮ** *ф. к.* **чапыр-чопыр итү**. *Шунлыктан, без көймә артында бераз чапыр-чопыр килеп йөзеп йөрдек – һава салкынча булса да, су үзе җылы сөттәй парлы, рәхәт иде.* Т.Нурмөхәммәтов

**ЧАР** I *и. фар.* Кискеч коралларны үткенләү өчен, таш яки комкайрак түгәрәк яки әйләндерерлек итеп беркетелгән шундый түгәрәге булган җайланма. *Хәзер алар тәрәзә яңакларына тотыначаклар – димәк, аркылы балта да кирәк булачак, ә анысын, көйләү генә түгел, чарга ук тотып аласы бар; наструк тимерләренә ике көн инде кайрак, беләү тигәне юк.* Х.Сарьян. *Малаеның кулы эшкә ятуын күреп, әтисе үзе үк бирегә верстак, тиски, электр чары ише нәрсәләр кертеп тутырды.* А.Гыймадиев

**ЧАР** II *и. лат. иск.* Рус патшасы

**ЧАРА** I *и. фар.* 1) Мөмкинлек; юл; чыгу юлы; котылу юлы. *Каршылык яки тәкәбберлек күрсәтү эшне генә бозачак, буйсынмыйча чара юк иде.* В.Имамов. *Башка чарам булмагач, аларга ияреп, чирек сәгать эчендә бөтен шәһәрне айкап чыктым.* А.Тимергалин

2) Берәр максатка ирешү өчен кулланыла торган эш-хәрәкәт, алымнар җыелмасы. *Шуңа күрә шәһәр белән авыл аермасын бетерү чараларын без инде күңелдән беләбез.* В.Нуруллин. *Әйт инде шул чараны, анакай бикә, җанымны өзсәм өзәм, мин ул чараны башкарып чыгачакмын, улымны тормышка кайтарачакмын!* Г.Гыйльманов // Кемгә дә булса тәэсир итү өчен эшләнгән гамәлләр. *Этә-ега, дәртләндерә стимул дигән чара ---.* Г.Афзал

3) Эш-хәрәкәт башкару, берәр эшчәнлек алып бару, фикерне җиткерү өчен хезмәт итә торган корал, арадашчы. *Туган тел кешенең һәм халыкның рухи табигатенең асылын тәшкил итә һәм кешене тәрбияләүдә, белемле итүдә иң көчле чара булып тора.* А.Тимергалин. *Сөйләмнең телдән башка аралашу чаралары да – әнә шундый махсус өйрәнерлек.* Р.Абдуллина

4) Берәр максат белән үткәрелә торган җыен, җыелыш, бәйрәм һ.б. *Тыйнаклыкка килгәндә, шагыйрь төрле очрашуларга атлыгып тормый, рәсми чараларда алга сикереп чыкмый иде.* Г.Гомәр. *Авылда бәйрәмнәр, культура чаралары уздырыламы?* З.Хәким

◊ **Чара күрү** 1) Максатка ирешү өчен берәр эш-гамәл кылу, юлын эзләү. *Газинур да тиешле чараларны күрә тора.* А.Хәсәнов. *Хуҗа карчык Азатның кем икәнлеген бик яхшы аңлый һәм малайны хакимиятләрдән саклау өчен чарасын күрә башлый.* А.Тимергалин; 2) Ярамаган, тиешле булмаган эш өчен җәза бирү. *Нечкәбил, киңәш бир, бу каракларга ни чара күрергә?* А.Гадел. **Чара кылу** *ялг. к.* **чара күрү**. *Ул егеткә берәр чара кылырга кирәк...* Г.Каюмов. **Чарасына керешү** Максатка ирешү юлларын эзләү. *Эш шунда: Зариф абыйсы аны теге Гамбәр туташ белән таныштыру чарасына чынлап торып керешкән икән.* Ә.Еники. *Шулай да чарасына керешкәч, вөҗүдкә чыкмый калмый инде.* Г.Әпсәләмов. **Чарасына керү** *к.* **чарасына керешү**. *Чарасына керми булмый, иптәшләр.* Н.Хәсәнов

**ЧАРА** II *и. фар.* 1) Әвәләнгән ипиләрне салып тору өчен, агач яки салам, чыбык, мунчала һ.б.дан үрелгән савыт. *Саламнан чара үрү*

2) Камыр басу өчен зур агач савыт. *Икмәкне чарада басу*

**ЧАРАСЫЗ** *с.* **1.** 1) Мөмкинлеге булмаган, чара тапмаган. --- *Козьма байтак айлар буе кенәз хатыны Байгөлгә гашыйк, һәм кайчандыр, җан атып, Андрей ягына күчкән пәһлеван хәзер үзен чарасыз бер әсир шикелле тоя иде.* В.Имамов. *Ул, күз алдында кечерәеп калган чарасыз мәхлук булып, калтыранып басып торуын белде.* М.Кәбиров

2) Чарасын табып булмаган. *Тынгысыз җаны үзенә урын эзли торгач, өермә кебек бөтереп, чарасыз сагышлар канатында туган туфрагыннан кубарып, әллә кайларга алып китте...* Р.Хәбибуллина. *Ничек кенә коткарырга бу бичараны мондый чарасыз афәттән?* Н.Сәйяр

**2.** *рәв. мәгъ.* Ихтыярсыз, теләсә-теләмәсә дә, ничарадан бичара. *Чарасыз керергә мәҗбүр булды Гөлмәрьям.* Ф.Абдуллин. *Исләргә төшәсең, Үзәкне өзәсең, Күзләрем чарасыз дымлана...* Г.Каюмов

**ЧАРАСЫЗДАН** *рәв.* Башка мөмкинлеге булмаганнан; аптыраганнан; ирексездән. *Ләкин ханым эченнән бик тарсына, бик ашкына, тик һичбер сылтау*

*булмаганга, чарасыздан гына тыныч гомер сөргән кебек йөри иде.* Г.Ибраһимов. *Тегесе исә, бары тик чарасыздан гына әйтергә мәҗбүр булган кеше сыман, зәһәрләнеп агу чәчә башлады...* М.Хәсәнов

**ЧАРАСЫЗЛЫК** *и.* Аптырау хәле; башка юл, мөмкинлек булмау. *Сары йорт үзе исә – хокуксызлык, чарасызлык, кеше кадере булмауның символы.* А.Гыйләҗев. *Маһинур әби, чарасызлыктан гаҗиз булып, ишекле-түрле йөренергә кереште.* Ф.Хуҗин

**ЧАРА́ ТАБАК** *и. к.* **чара** II. *Мәймүнә түти буы чыгып торган чикмәнле бәрәңгене, чара табакка тутырып сосып, табын уртасына китереп утыртты.* М.Гали

**ЧАРАЧА** *и. фар. диал.* 1) Мунча алды. --- *чарачадан (ул анда бүген көндез мин сындырып алып кайткан каен ботакларыннан мунча себеркеләре --- бәйләп утыра; ул пиннекләр, мәтрүшкәләр, шомырт, карлыган ботаклары кушкангадыр инде, гаҗәеп хуш исле була) тагын әнинең тавышы ишетелде ---.* Ф.Төхбәтуллин

2) Өйалды. *Якты чарача*

**ЧАРГӨЛ** *и. фар.* Гөлчәчәклеләр семьялыгыннан кыска сабаклы, ак чәчәкләре йөрәктәй аерчалы күпьеллык үсемлек; каз үләне; *русчасы:* **лапчатка белая**

**ЧАРДАК** *и. фар.* 1) Биналарда түбә һәм түшәм арасындагы урын. *Һәм чардактагы куышына, ашыгып, мине алмагач төбендә ялгызымны калдырып менеп китте.* М.Хуҗин. *Озак уйлап тормый, өй түбәсенә – чардакка менгезеп куйдым моны.* Н.Кәримова

2) Өйнең яшәү өчен яраклаштырылган шул урыны // Өйнең алгы ягында түбә кыегы белән түшәм арасында ясалган балкон кебек янкорма; мезонин. *Әкиятләрдәге тылсымлы тирмә диярсең: сап-сары нарат бүрәнәләр, бизәкләп, челтәрләп эшләнгән тәрәзә рамнары, икенче катта – челтәрле чардак, өй түбәсендә чит-читләре бизәкләп киселгән кызыл калай.* Ф.Бәйрәмова

3) *күч. сөйл.* Баш; акыл. *Чардагы эшли*

**ЧАРДАКЛЫ** *с.* 1) Чардагы булган. *Ә без чардаклы күк йортта тыныч кына торып ятабыз.* Ә.Еники. *Хәби хәзер Рөстәмбәкнеке шикелле чардаклы йорт төзергә хыялланып йөри, ди.* В.Имамов

2) *күч.* Акыллы, башлы. *Аларның бабалары да бик чардаклы булмаганнар булса кирәк.* Ф.Хөсни

**ЧАРДА́К ӨЙ** *и.* Түбә астында ук яшәү өчен яраклаштырылган кыек түшәмле бүлмә; мансарда

**ЧА́РДАШ** *и. венг.* Хәрәкәтләр салмактан кызу темпка алышынып торган венгр халык биюе һәм шул биюнең көе. *Хәйрушка Венгриягә кунакка килә. О, Венгрия! О, чардаш!* А.Гыйләҗев

**ЧАРДУГАН** *и. фар.* Каберне уратып алган агач яки тимер рәшәткә, койма. *Чардуган эченә борынгы хәрефләр белән чокылган таш утыртылган.* М.Мәһдиев. *Каберләр өстенә буралап корылган чардуганнар да караеп, череп беткәннәр.* А.Тимергалин

**ЧАРЛАК** I *и. фар. к.* **чардак**. *Әмма көтүче аталары иске киемнәре белән чыбыркыны зур сарайларының башына – чарлакка менгереп асып куя.* Әкият. *Бүлмәсе яртылаш чарлакта диярлек, аның каравы моннан бөтен тирә-юнь күренеп тора, һәм кереп-чыгып йөрү урыны да аерым.* Ә.Мушинский

**ЧАРЛАК** II *и. зоол.* 1) Акчарлак кошлар семьялыгыннан озын тар канатлы, карлыгачныкыдай уенты койрыклы, диңгез, елга, күл яр буйларында яшәүче кош; крачка

2) *диал. к.* **акчарлак**

**ЧАРЛА́К ӨЙ** *и. к.* **чардак өй**. *Чарлак өйнең тәбәнәк стенасына сөяп куелган иске чемодан да буш иде, ахрысы, мин аны күтәреп карагач, бик җиңел булып чыкты ул.* Т.Нурмөхәммәтов

**ЧАРЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **чарлау**. *Эш кораллары һәммәсе тәртиптә – җиңел итеп сапланган, шомартылган, чарланган, майланган булыр.* Л.Ибраһим-Вәлиди

2) *кайт. юн. к.* **чарлау**

3) *күч.* Тәҗрибәле, белемле, үткен булып китү; остару, шомару. *Кызыл Армиядә хезмәт итеп кайткан, дип ишетеп калган идем, димәк, күпме-азмы чарланган егет!* Ә.Еники. *Фатих матур гына киенә, читтә йөреп чарланган, теле телгә йокмый, ярату сүзләрен сибә генә.* Д.Каюмова

4) *күч.* Төгәл мәгънә белдерә башлау, төзек хәлгә килү; камилләшү (тел, стиль һ.б.ш. тур.). *Китап инде автор тарафыннан да кат-кат эшләнгән: чарланган, редакторның таләпчән кулыннан да үткән.* М.Шабаев. *Һәрбер халыкның гасырлар буе чарланган мәзәкләре бар.* Т.Нәҗмиев

**Чарлана бару** Торган саен ныграк чарлану. *Җиңелү дигән нәрсәне белмәгән легендар яугир тормышының иң киеренке мизгелләрен чагылдырган әлеге әсәрләр Европа халыклары күңелендә, телендә чарлана бара һәм бернічә гасыр буена яши.* Ф.Урманче

**Чарлана башлау** Чарланырга тотыну. *Шуның өстенә, алларында Хәсән торган бу үсмерләр мәдрәсәнең эчке һәм тышкы сәясәтләрен бик яхшы аңлап, шәкертләрнең актив хәрәкәтендә чарлана башлаган чая егетләр булып чыктылар.* С.Кудаш

**Чарлана килү** Электән үк, күптәннән чарлану. *Татар халкының тарих түреннән чарлана килгән гореф-гадәтләренә туры килеп бетми торган фәлсәфә!* А.Әхмәдуллин. *Хәзерге шигърияттебезнең кодрәте, сурәтлелек байлыгы татар поэзиясенең гасырлар дәвамында чарлана килгән төрле чыганакларын үзләштереп, яңача үстерә белүендә.* Т.Галиуллин

**Чарлана төшү** Бераз чарлану; тагын да чарлану. *Төрле шәһәрләрдә йөри торгач, Рәзит шактый чарлана төшә.* Кызыл таң

**Чарланып бетү** Бик нык чарлану. *Кайдан сүзен таба, концерт-спектакль куеп, тәмам чарланып беткән.* З.Мурсиев

**Чарланып җитү** Кирәк кадәрле чарлану; тиешле дәрәҗәдә чарлану

**Чарланып килү** Әлегә кадәр чарлану; чарлана башлау. *Ул да булса, безнең милли тамырларыбыз халыкның, бигрәк тә авыл кешеләренең гасырлар дәвамында сакланып һәм чарланып килгән гореф-гадәтләренә барып тоташа, – аларга тугрылык сакларга кирәк!* А.Әхмәдуллин. *Тел – ул буыннан-буынга чарланып килгән рухи байлыгыбыз.* Р.Вәлиев

**ЧАРЛА́У** *ф.* 1) Кисү коралларын чарда үткенләү. *[Пычакның] Йөзе начар иде, үтмәс кебек иде. Казанга кайтырга уйлады, анда бушлык иде. Барыбер чарлар дип, чүлмәкнең читенә бернічә тартты.* Г.Ибраһимов

2) *күч.* Тәҗрибәле, акыллы, эш йөртә белгән кешегә әйләндерү; өйрәтү; яхшырту; үзгәртү. *Бөкрене кабер генә төзәтә, дигәндәй, аны төрмә дә чарлый алмаган, хәрби хезмәт игәве дә игәп җиткерми, һәр чебеш йомырканы үзе тишеп чыга.* С.Поварисов

3) *күч.* Эшкәртү, камилләштерү; мәгънә, форма, яңгыраш ягыннан төзек, төгәл итү. *Юраганы юш килсен өчен, Фәнис күп тырышты: укыды, язды, бертуктаусыз шигъри каләмен чарлады.*

М.Шабаев. *Талантны һәркем үзе үстерә, аны тыелгысыз-ашкынулы, юк, фидакяр хезмәте белән чарлый.* М.Хуҗин

4) *күч. сөйл.* Кыйнау. *Мондый хәлдә колакны йолкып кына калмыйлар, күлмәкләребезне, хәтта ыштаннарыбызны салдырып, чыбык белән чарлыйлар.* Г.Ибраһимов турында истәлекләр

**Чарлап алу** Тиз арада чарлау

**Чарлап ату** Бик тиз чарлау

**Чарлап бетерү** Яхшылап чарлау; барысын да чарлау

**Чарлап җибәрү Бераз чарлау.** *Аракы минем телне шактый чарлап җибәрде. Урысча акцентым да сизелми башлады.* Н.Акмал. *Балаларның аналарга карата булган хисләрен менә шулай чарлап җибәрү дә бик кирәктер!..* Р.Баттал

**Чарлап җиткерү** Тиешле дәрәҗәдә чарлау. *– Ук тимәсә, аткан белән кош үлмәс, ди, морза, димәк ки, сөмәкләрегезне чарлап җиткермәгәнсез, фаразан, – дип чеметеп алды Давы бахшы.* М.Әмирханов

**Чарлап тору** Әледән-әле, даими чарлау; әле, хәзер чарлау. *Менә бит әле син чарлап торасың...* М.Яһудин

**Чарлый бару** Рәттән чарлау; һаман яхшырак чарлау. *Ул беренче адымнарын тыйнак кына башласа да, әмма әсәрдән-әсәргә осталыгын чарлый барып, берсеннән-берсе уңышлырак әсәрләр тудыра.* А.Хәйруллина

**Чарлый башлау** Чарларга тотыну. *Ил агасы – олпат әдипләр белән дә, әле яңарак кына каләм чарлый башлаган яшьләр белән дә үз итеп гәп кора, бәхәсләшә, аралаша иде ул.* Казан утлары

**Чарлый тору** Әлегә чарлау; кабат-кабат чарлау. *Шулай төзәткәли, чарлый торгач, соңгы басмада бу урын шактый ук җыйнакланды шикелле ---.* Г.Бәширов. *Җиргә төшкән чыпчыкны эләктерергә тырнак чарлап торганда, чыпчык очып киткәч, мәче баласы ничек караса, Гамил кулындагы дәфтәргә шулай карап калды Гөлүсә.* Г.Сабитов

**Чарлый төшү** Берникадәр чарлау; тагын да чарлау

**ЧА́Р-НАЧАР** *рәв. фар. иск.* Чарасыздан, теләсә-теләмәсә дә, ничарадан бичара

**ЧАРПАЛАНУ** *ф. диал.* Чәрдәкләнү, ярылу

**Чарпаланып бетү** Бик нык чарпалану. *Ваһап тубы тузып, чарпаланып беткәнче ата, үзе дә яралана.* Г.Кашшаф

**Чарпаланып китү** Соңгы арада чарпалану

**ЧАРПАЛАНЫШ** *и. диал. к.* **чарпылыш**. *[Тукайның] бу омтылышы аеруча киеренке төс алып, анда иске һәм яңа караш-идеяләрнең чарпаланышын, каршылыклы аралашуын --- очратырга мөмкин иде.* Г.Халит

**ЧАРПАЛА́У** *ф. диал.* Чәрдәкләү, яргалау, телгәләү

**ЧАРПАЛУ** *ф. диал.* Чәрдәкләнү

**ЧАРПЫЛУ** *ф.* Тавыш чыгарып бәрелү. *Кылычы аның Яшьлеге кебек Уйнаган, диләр, – Чыңлаган, диләр; Чарпылып яуда, Бөгелгән кайчак, Сыгылган кайчак – Сынмаган, диләр.* С.Хәким

**ЧАРПЫЛЫШ** *и.* Бәрелеш, капма-каршы килеш, зур бәхәс. *Әгәр Еники белән Мәһдиевтә чорның социаль каршылыкларын аңлау, шул каршылыклар чарпалышында үз төп урыннарын билгеләү көче дә булса, алар татар тормышын дөнья мәйданына чыгарырлык әсәрләр яза алыр иде.* Ә.Закирҗанов

**ЧАРПЫЛЫШУ** *ф.* 1) Бәрелешү

2) Капма-каршы килү. *Икесенең күз карашлары чарпылышкан вакытта, Хәлим бу агайның күзләрендә кешене өтеп ала торган дошманлык сизә иде.* И.Гази. *Фикерләр чарпылышты, икесе дә, немецның хәйләсен төшенергә теләп, үзенең гөманын әйтә иде ---.* Х.Камалов

3) Аркылы-торкылы килү, үрелеп, чуалып бетү

**Чарпылышып бетү** Бик нык чарпылышу. *Күгелҗем урман өсләреннән башларын сузган ерак вышкалар, челтәр баганалар, чарпылышып беткән электр чыбыклары аның бөтен барлыгын биләп алдылар.* Г.Ахунов

**ЧАРПЫШ** *и. сөйл. к.* **чарпылыш**. *Һадигә дә шулар, Нәҗмигә дә үчле. Алар калды чарпыш эчендә. Ә мин менә – сезгә кайттым әле Ныгыр өчен бераз, эшчеләр.* Х.Туфан

**ЧАРПЫШУ** *ф. сөйл.* 1) Бәрелешү; бәргәләнү. *Авазның беренче дулкыны, урамнарга сыеша алмыйча, авыл өстендә чарпышып барганда, йомшак һаваны тетрәтеп, өндәүченең соңгы сүзләре шыңгырдап куйды.* Г.Бәширов

2) *күч.* Көрәшү; бик нык бәрелешү. *Торма монда юк көчең берлән талашып, чарпышып, Өскә чыкты инде хаклык ---.* М.Җәлил

**Чарпыша башлау** Чарпышырга тотыну. *Һәм чарпыша башладылар шәфкатьсез, чигенүсез. Кайсы җырны кем җырлаган – төшенерсез үзегез ---.* С.Баттал

**ЧАРТ** I *иярт.* Агач, сөяк сынганда, утын ярганда, каты итеп сукканда һ.б.ш. очракларда чыккан яңгыравык тавышны белдерә. *--- агачлар исә һәркаюсы һаваның суыклыгыннан хәбәр бирә: каюсы чарт, каюсы чырт дип кычкырып җибәрә ---.* З.Һади. *Тынлыкта тик күрше кызы Мәликәнең чарт та чорт сагыз чәйнәве генә ишетелеп торды.* Г.Бәширов

◊ **Чарт ярып** *к.* **чартлатып**. *Миңнулланың «аңладыгызмы» дип сорагании да көтмичә: – Күптән шушылай чарт ярып әйтеп бирергә кирәгие аны!* В.Нуруллин

**ЧАРТ** II *и. ингл.* Популяр җырчыларның, башкаручы төркемнәрнең сатылган альбомнарын һәм дискларын исәпләү нигезендә төзелә торган һәм даими игълан ителеп торган исемлеге. *«iTunes» чартларын яулау*

**ЧА́РТЕР** *и. ингл. махс.* 1) Милек иясе белән яллаучы төзегән диңгез яисә һава судноларын яки аларның берәр өлешен арендага алу турындагы килешү. *Саф чартер*

2) Шундый килешү төзелгән һава яки диңгез судносы; шул судно ясаган рейс. *Моңа кадәр һава ширкәте очкычлары Әстерханга да чартер белән барган булган.* Н.Алан

**ЧАРТИЗМ** *и. ингл. тар.* XIX йөздә инглиз эшчеләренең сәяси һәм икътисади хәрәкәте. *Чартизмның юлбашчылары*

**ЧАРТИСТ** *и. тар.* Чартизм тарафдары. *Кайда синең Чартистларны биргән, Маратларны биргән илләрең?* Х.Туфан

**ЧА́РТ ИТҮ** *ф.* Чарт сыман тавыш чыгару. *Шул арада берсе чарт итеп сагызын чартлата ---.* М.Мәһдиев. *Ну кайтып йокларга яткач, кирәген бирдем үзенең дә: юрганын иплән кенә ачтым, гырылдаган авызына карап тордым, аннары борынына чарт резин белән.* Ф.Яруллин

**ЧАРТЛАТУ** *ф.* Чарт иткән тавыш чыгару. *Апаларының кызып-кызып тема аңлаткан вакытында, рөхсәт тә сорамыйча, ишектән кергән һәм чартлатып битенә төкергән ир-атны күрүдән балалар телсез калгандай булды.* Р.Рахман

**Чартлатып алу** Бер тапкыр чартлату. *– Һи-и, сезнең белән авыз чайкап ятарга монда, – дип, Зөлхәбирә сагызын гына бер чартлатып ала иде.* М.Мәһдиев

**ЧАРТЛАТЫП** *рәв.* Курыкмыйча, дөрес итеп. *Әнә шуларның барысы ту-*

*рында завхоз Исмәгыйль чартлатып җавап биреп тора, ди...* М.Мәһдиев. *Укучылар җырның сүзләрен дә ятлаган, чартлатып сөйләп тә бирделәр, бергәләп җырлап та алдылар.* Р.Газиз

**ЧАРТЛА́У** *ф.* Чарт итү, чарт иткән тавыш чыгару. *Чүриле урыслары хач манган көн кышның иң суык вакыты, йорт бүрәнәләре чартлаган, чишмәләр бозга каткан, иртә туган сарык бәрәннәре абзарда өшегән вакытлар була иде.* М.Мәһдиев. *Фәргатьнең кулы чартлап стенага бәрелде.* Ф.Садриев

**Чартлап кую** Көтмәгәндә чартлау. *Алда кинәт яшен чартлап куйды – Һич тә көтми идем монысын.* З.Мансуров

**Чартлап тору** Даими, әледән-әле чартлау; әле, хәзер чартлау. *Үлем хәбәре килгән көннәрдә бүрәнәләр чартлап торган салкын төннәр иде.* М.Мәһдиев

**Чартлый башлау** Чартларга тотыну. *Аның тавышы тагын чартлый башлады.* М.Мәһдиев

**ЧА́РТ-ЧОРТ** *иярт.* Утын янганда, чыбык сынганда, чыбык белән берничә кат сыдырганда, махсус төймәләргә катырак басканда һ.б.ш. очракларда чыккан өзек-өзек тавышны белдерә. *Фәнис, үгезнең каршысына төшеп, мөгезләренә чыбык белән чарт-чорт бәрде.* Ф.Садриев. *Чанасындагы тартмадан кечкенә генә касса аппараты тартып чыгарды да, эшлекле кыяфәт белән, чарт-чорт аппарат төймәләренә баса башлады.* Ф.Имамов

**ЧА́РТ-ЧОРТ ИТҮ** *ф.* Чарт-чорт килгән тавышлар чыгару. *Аяк очында гына чарт-чорт итеп учак дөрли.* З.Мәхмүди. *Чарт-чорт мылтык чакмасы киергән тавышлар ишетелде.* Р.Батулла

**ЧА́РТ-ЧОРТ КИЛҮ** *ф. к.* **чарт-чорт итү.** *Шуның аксыл тәгәрмәчен бик каты әйләндергәч, металл щёткалары чарт-чорт килә.* М.Мәһдиев

**ЧА́Р-ЧАР** *иярт. к.* **чыр-чыр**. *Йөгереп керде дә, ди, кешене ишетми, чар-чар үзенекен сөйләп, минем сумкага килеп ябышты, ди.* Безнең гәҗит

**ЧА́Р-ЧАР ИТҮ** *ф.* Чар-чар килгән тавыш чыгару

**ЧА́Р-ЧАР КИЛҮ** *ф. к.* **чар-чар итү**

**ЧА́Р-ЧОР** *иярт. к.* **чыр-чыр**. *Бередә --- сатучылар чар-чор кычкырып тора.* Кәеф ничек?

**ЧА́Р-ЧОР ИТҮ** *ф. к.* **чар-чор килү**

**ЧА́Р-ЧОР КИЛҮ** *ф.* Чарылдау. *Фәтхерахман, боларны нәрсә белән туйдырырга аптырап, уйланып торганда, арттан чар-чор килгән хатын-кыз тавышлары ишетелде.* К.Тинчурин

**ЧАРША́У** *и. фар.* 1) Бүлмәнең йокы урынын, берәр почмагын каплау яки аеру өчен эленгән тукыма пәрдә. *Беркөннәрне Мәңгәр Йосыфларның ишек чаршауларын күреп исем китте.* Г.Камал. *Тәрәзәгә ак пәрдә, уртага өрәңә яшел чаршау элделәр.* Г.Бәширов

2) Ширма. *Сакчылар җыелмалы чаршау – ширма алып киләләр.* А.Гадел

3) *сөйл.* Пәрдә (сәхнәдә). *Тиздән сәхнә алдына чаршауны аралап, тел бистәсе чыгачак та барча артистлардан чук-чук сәламнәр күндерәчәк.* Ә.Баян

4) *иск. к.* **чадра**

5) *күч.* Томан, караңгылык. --- *төн чаршавы аны улыннан каплап торды.* А.Хәлим

6) *күч.* Берәр нәрсәдән качу, үз-үзеңне аклау чарасы; сылтау. *Менә шул кыргый инстинктны дини яисә идеологик чаршаулар белән капларга омтылу – һәр чорның террорчыларына да хас әйбер.* Р.Зәйдулла

**ЧАРШАУБИКӘ** *и. кимс.* Сөяркә; фахишә. *Нүгәрләр, ихахайлап, Маруся белән күңел ачып ятуда. --- Чаршаубикә генә чыдасын!* З.Мәхмүди

**ЧАРШАУЛЫ** *с.* 1) Чаршау белән бүленгән; чаршау эленгән. *Ләкин аларны, куркытып, сайлау бара торган мәчет бинасына алып килделәр, куллырына алсу, зәңгәр, ак төстәге кәгазьләр бирделәр һәм, мәҗбүри рәвештә, чаршаулы бүлмәләргә кертеп җибәрделәр.* М.Мәһдиев. *Үзем дә шушы моңга бирелеп, тыныч кына чаршаулы бишекнең тирбәлүен күзәтеп утырам.* М.Садыйков

2) Бөркәнчек ябынган, чадралы. *Ул арада тагы берничә чаршаулы (бөркәүле) ханымнар килеп чыкты.* Г.Исхакый

**ЧАРШАУЛЫК** *с.* **1.** Чаршау тегү өчен яраклы булган, шуңа дигән. --- *чаршаулык яхшы плүш тә әйтермен дигән идем.* Г.Камал

**2.** *и. мәгъ.* Чаршау тегү өчен тукыма, материал. *Ул андагы төрле ситсы товар, кием тышлыгы, яулыклар, чаршаулыклар!* Г.Бәширов. *Бүләкләреңне барла, урыныңдамы бар да? Мендәрләр, чаршаулыклар, сөлгеләр, ашъяулыклар...* М.Мәһдиев

**ЧАРША́У-ПӘРДӘ** *җый. и.* Чаршау, пәрдәләр һ.б.ш. кирәк-ярак. *Нәҗип яшерен өмет белән кече якка карашын ташласа да, чаршау-пәрдә селкенмәде, чәй янына май-шикәр чыкмады, күпереп торган авыл ипие дә, корт та, төче катлама да, бүтән төрле сагынылган сыйлар да юк иде.* А.Гыйләҗев. *Күрми күргән чабатасын түргә элгән, дигәндәй, Миңлениса үзе алып килгән чаршау-пәрдәләре белән стена-тәрәзәләрне генә түгел, хәтта өйалды ишегенә кадәр бизәкләде.* В.Имамов

**ЧАРША́У-ЧАРШАУ** *с.* Зур, күләмле. *Бу җиңү – чаршау-чаршау татарча гәзитләр чыгару, татар техникасының алга китүе, татар халкының бөтен дөньяны шаулатуы – төштә генә булып чыга, төш күрүче хыялый уянып китә.* Р.Батулла

**ЧАРШЕЛ** *и. к.* **чаргөл**

**ЧАРШЫН** *и.* Бал корты икмәге, чыршын. *Безнең тикшеренүләребез буенча, мәсәлән, баса (ирчәчәкле киндераш), бирән (күп ашаучы), --- чаршын (бал корты «әпәе»), чыны (киләп бавы) --- сүзләре борынгы болгар теленнән киләләр.* Р.Әхмәтьянов. *Пичәтләнмәгән кәрәзле баллы рам, чаршын һәм яшел масса бер тәүлек эчендә ветеринар лабораториягә җибәрелә.* Сарман

**ЧАРЫК** I *и. фар.* 1) Су тегермәнендә, пароходта күп калаклы зур тәгәрмәч; куласа. *Хәзер инде ул элеккеге мотор түгел, ә көчкә-көчкә генә әйләнә торган тегермән чарыгы.* А.Хәсәнов

2) Сәгатьтә һ.б. механизмнарда тешле тәгәрмәч; йолдызча. – *Сугу машинасының валын әйләндерә торган чарыгы ярылды! – ди.* В.Нуруллин

**ЧАРЫК** II *и. иск.* Тула кунычлы, күн олтанлы аяк киеме. *Алар арасында энә-җеп, уймак ише вак нәрсәләр, без, хәтта шөшле, урак, пычак, хәнҗәр, кайчы --- баш киемнәре, тула оеклар, киез итек, сырма, чарык, йомшак күн --- һәм башка әйберләр бар иде.* А.Тимергалин

◊ **Чарыгы таю** Хәлдән килмәү

**ЧАРЫЛДА́У** *ф.* 1) Югары, нечкә тавыш белән кискен авазлар чыгару. *Кайдадыр күктә каргалар чарылдады.* Г.Кутуй. *Мәчет манарасы тирәсендә чәүкәләр чарылдап оча.* Г.Сабитов

2) Ямьсез, кискен тавыш белән кычкырып сөйләшү, көлү, елау һ.б.ш; чыелдау, чәрелдәү. *Аста чарылдап кычкырган бала-чага, хатын-кыз, карт-коры тавышы ишетелеп китә.* Р.Сәгъди

**Чарылдап җибәрү** Кисәк чарылдау. *Корсагы белән басмага яткан һәм ике кулы белән капчыкка чатырдап ябышкан хәлдә, үзе дә сизмәстән, иләмсез рәвештә чарылдап җибәрде.* Ә.Баян

**Чарылдый башлау** Чарылдарга тотыну

**ЧАРЫЛДЫК** *с. к.* **чәрелдек**. *Тагын берничә минут узса узгандыр – бирегә, гомер күрелмәгән мул бәйрәм табынына, чарылдык акчарлак халкы җыелган.* А.Тимергалин

**ЧАРЫС** *с.* 1) Йөгерек, елдам (ат тур.) // Кызу, чыгымчы, кыргый холыклы

2) *диал.* Тырыш, эшкә җитез; чая, үткен (кеше тур.) // Кызу, кырыс холыклы

**ЧАСО́ВНЯ** *и. рус* Христиан динен тотучылар гыйбадәт кылу өчен, алтарьсыз кечерәк бина. *Иң ахырда, караңгы төшәр алдыннан, басуга, юл чатындагы часовня янына алып менделәр.* Г.Бәширов

**ЧАСОВОЙ** *и. рус* Сакта торучы, корал белән каравылда торучы гаскәри. *Почмактан караган иде, капка төбендә фонарь яктылыгында винтовка тоткан часовой бөрешеп тора.* Ә.Мушинский

**ЧА́СТНИК** *и. рус. сөйл.* 1) Шәһәр җирендә үз йорты белән яшәүче

2) Кечкенә эшханә тотучы хуҗа, вак хосусый милекче. *Частникларны милиция дә куркыткалады, аягына ялтыравыклы күнитек, башы белән өстенә яшел фуражка һәм френч кигән райкомхоз кешесе дә кугалап торды.* Т.Нурмөхәммәтов. *Частник мин хәзер, үземә үзем хуҗа*. Р.Габделхакова // Гомумән, җитештерү, хезмәт күрсәтү һ.б. өлкәдә вак индивидуаль эшмәкәр

**ЧАСТЬ** *и. рус* 1) Берәр корал, җиһаз, механизмның кисәге, детале. *Запас частьлар председатель кесәсендә йөрми торгандыр бит, завхоз кулында булырга тиештер ич алар!* В.Нуруллин. *Ләкин майланган частьларын җыя башлагач, Әлтафи бераз аптырап калды: тегеләй итеп тә, болай итеп тә карады, әмма дәү сәгатьнең нәкъ бер кушуч шестернялары артып кала иде.* М.Мәһдиев

2) Гаскәри берәмлек. *Чөнки төп хәрби частьлар, штаб, азык-төлек складлары, резервтагы командирлар ашханәсе шунда.* М.Шабаев. *Задание: авылда нинди часть тора, штаб йорты кайда, таш юлдан нинди техника килә – һәммәсен дә хәтергә алырга.* М.Мәһдиев

3) *тар.* 1917 елгы революциягә кадәр шәһәрнең аерым участогы һәм полиция идарәсе

**ЧАТ** I *и.* 1) Ике яки берничә урам яисә юл кисешкән урын. *Менә, узып барышлый, чатта гәҗит сатып алдым да бер бик кызыклы игъланга күзем төште.* А.Гадел. *Туташ белән Декабристлар – Восстание урамнары чатында очраштык.* Г.Гомәр

2) Үзара кисешкән сызыклар, турылар; үзәгеннән чыккан тармакларның һәрберсе. *Рәсемдәге ике чаты югары карап торган билгене без җир символы дип, чаты аска карап торган әлеге билгене күк символы дип исәплибез.* Н.Фәттах. *Мәскәүдә --- элекке Симон монастыре урнашкан урында XX гасыр ахырларында ачылган борынгы каберләрне каплап торган таш плитәләргә гадәти тәре түгел, бәлки үзәктәге розеткадан (ул калканга охшаган) аска таба бер туры чат, өскә таба ике кәкре чат сузылган сурәт төшерелгән.* А.Тимергалин

3) Ярь, тармак. *Нәрсәгә кирәктер аңа утынлыктагы тутыккан балталар, чаты сынган сәнәкләр?* Ф.Яруллин

4) *диал.* Берәр предмет, бинаның почмагы. *Алып кайканда, буханканың бер чаты кимерелеп бетә, урам буенча чемченеп кайтуы нишләптер бик тәмле була иде.* Т.Нурмөхәммәтов

◊ **Чат саен** Бөтен җирдә; теләсә кайда. *«Болгар» оешмасыннан булмаса да, Мәскәүдә күптән түгел генә «Болгар» театрын оештырдым, дип чат саен сөйләгән Гөлфирә бүген дә шушы өстәлләр тирәсендә бөтерелә.* Н.Кәримова

**ЧАТ** II *и.* Кешедә оча сөягенең түбәнге өлеше, кошларда бот янындагы сөяк. *Чат сөяге авырту*

◊ **Чат ачылу** 1) Тавык, каз кебек кошларның күкәй салу алдындагы хәле; 2) Уйный-көлә, күп сөйләшә башлаган кеше турында

**ЧАТ** III *кис. сөйл.* **1.** 1) Бөтенләй, тулысы белән, гел; нәкъ. *Чат сеңер, эче тәмле җелек белән тулы сөякне, я әйтегез, кем генә яратмый инде аны?!* А.Хәсәнов. *Ә үзең тотынгач, моның бер дә үрчеми торган четерекле эш булуы күренде: башта чат үз урынына утыргандай тоелган китекне кире кубарасы, каткан җилемнән чистартасы була.* А.Тимергалин

2) Тоташ. *Чат мәрмәр дә пыяла гына икән бу залы!* Г.Әпсәләмов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Бик нык; гел; тулысы белән. *Без белгән бәлшәвичкә дә күн тужуркалы, төс-кыяфәте белән дә Коллонтайга чат охшаган иде.* Г.Гомәр. *Иртәнге чыкка чыланып, билдән чат су булып, шушы аланга килеп керсәләр – тамаша!* А.Хәсәнов

2) Нәкъ, тач. *Боерган булса, чат тапкан кешесенә булыр әле.* А.Тимергалин

◊ **Чат ябышу** 1) Берәр кешегә иярү, бәйләнү, тынгылык бирмәү. *Ә Розага чат ябышуының сәбәбе башка: кызның ярып әйткән әлеге сүзе мин-минлегенә тигән иде Фәләхнең.* В.Нуруллин; 2) Берәр эшкә ныгытып тотыну, берәр нәрсә белән ныклап кызыксыну. *Солтанъяр бу кадәресен уйламаган иде: кара син аны, ять-яшь кыз, Степан дустының кызы дингә чат ябышып ята икән.* З.Мурсиев

**ЧАТ** IV *и. ингл.* Интернетта виртуаль очрашу, аралашу урыны. *Шул ук көнне чатта Альф дигән исем барлыкка килде, һәм Альф – Әлферит яшьтәшләре белән әңгәмә кора башлады.* А.Гыймадиев. *Энем Гайсә белән без чатта язышабыз ---.* Г.Шәйхи

**ЧАТА** *и.* Чатлы агач, ике тармакка аерылган агач. *Кәкре агачтан – кәкерчек, чатлы агачтан – чата.* Әйтем. *Ул вакыттагы мылтыктан аягөсте торып атканнар, мылтык көпшәсе, атканда, махсус чатлы таяк – чатага терәтелгән.* Р.Әхмәтьянов

**ЧАТА́Й-БОТАЙ** *с. к.* **чатлы-ботлы**. *Ул да чатай-ботай итеп хат яза ала да конверт тышына адрес яза белә.* С.Агиш

**ЧАТАК** *с. сөйл.* **1.** Начар, кимчелекле. *Чөнки миңа, бухгалтерия кешесе буларак, аның чатак эшләре билгеле.* Н.Хәсәнов. *Шуңа күрә егет тулай торакка яуда җиңүче сыйфатында башын горур тотып түгел, ә кәефе кырылып, төшенке күңел белән, эшләгән чатак эшеннән разый булмыйча, аннан шатлык-куаныч тапмыйча, канәгатьсез кыяфәттә кайтты.* Р.Кәрами

**2.** *и. мәгъ.* Ялгышлык, туры килмәү; кимчелек; казус. *Бүгенге май кичендә мунча искиткеч шәп буласы иде: Мәскәүдән килгән корреспондент белән чатак чыккач, үз-үзен битәрләп йөргән Исламнур бүген үзен күрсәтеп, яхшы атын кире кайтарырга тиеш иде.* А.Гыйләҗев

**ЧАТА́К-БОТАК** *с. сөйл.* Тәртипсез хәлгә килгән, буталчык

**ЧАТАКЛАНУ** *ф. сөйл.* Рәте китү, начарлану, кимчелекләр барлыкка килү. *Радио-телевидение дикторлары тарафыннан тетелә, урам язуларында чатаклана, өйдә генә кулланылып кимсетелә ул.* Р.Рахман

**ЧАТАКЛЫК** *и.* Туры килмәү; кимчелек, җитешсезлек; төгәлсезлек.

*Әзләсәң, үзеңнең хикәя, повестьларыңда да әллә күпме чатаклыклар табарга мөмкин.* Ә.Әминев. *Тәрҗемәдә алга таба да чатаклыкка юлыгабыз.* А.Тимергалин

**ЧАТАЛ** *и.* Ике япьле сәнәк. *Сыртакның тагын бер ысулы бар: ул ике җәпле агач чатал – сәнәк белән тере бүре тота, тота да, авызына артыш таягы тыгып, бүренең танавын кысып бәйли.* Р.Батулла

**ЧАТАН** *с.* **1.** Аягы имгәнгән яки зәгыйфь; аксак. *Әллә алгы якка теге кече ызбада яшәүче чатан солдатны гына күчерикме икән?* М.Хәсәнов. *Күп тә узмас, әлеге чатан көчек тә, этисе кебек, шушы урман хуҗасы булыр.* А.Хәсәнов

**2.** *и. мәгъ.* Имгәнгән, зәгыйфь аяклы кеше. *Сеңлесе бер чатанга кияүгә чыккан иде ---.* Ф.Садриев. *Аяксызын – аяксыз көе, чатанын – чатан көе, чулагын чулак көенчә яраталар.* Ф.Җамалетдинова

**ЧАТА́Н-БОТАН** *рәв. к.* **чатан-чотан**. *Казның бу җырын ишеткәч, сукыр дию бик куанган, шатлыгыннан чатан-ботан биеп алган.* Ф.Яруллин. *Сүз озайтмады Петя, чатан-ботан китте.* К.Кара

**ЧАТАНЙӨРӘК** *и. гади с.* Башкаларның эчке дөньясын аңларга теләмәгән тупас кеше; эгоист. *Ябык, озын гәүдәле Габделхәй үзен үзе, шаярткандай итеп кенә, чатанйөрәк дип йөртә иде.* М.Шабаев

**ЧАТАНЛА́У** *ф.* 1) Аксаклау, титаклау, аксаклап йөрү. *Бер кимчелеге бар иде Сафуанның: сул аягына сизелер-сизелмәс кенә чатанлый иде ул.* З.Мәхмүди. *Бер аягына чак кына чатанлап йөргән чем кара чәчле Ринат дустымны сез беләсез инде.* Т.Нурмөхәммәтов

2) *күч.* Җитешсезлек, кимчелек ясау; хата җибәрү. *[Зәйтүнә:] Димәк, болай булып чыга: монысы азрак чатанлады – эштән куыйк, тегесе азрак аксаклады – төрмәгә утыртыйк.* Х.Вахит

**Чатанлый башлау** Чатанларга тотыну. *Беркөн һич көтмәгәндә аның сивкасы нык итеп аксый, чатанлый башлый.* М.Зарипов

**Чатанлый төшү** Бераз чатанлау

**ЧАТАНЛЫК** *и.* 1) Аксаклык, чатан булу. *Хәтта бераз гына чатанлыгы да бар.* А.Хәсәнов

2) *күч.* Җитешсезлек, кимчелек. *Фәнни хезмәте дә бик нык ошады, берниндиаксау, туксау, чатанлык галәмәтләре күрмәдем.* Т.Галиуллин. *Менә шуңа, күрәсең, аның әсәрләрендә ишетер колакка ятыш булмаган нәрсәләр, ритмик чатанлык күренеше юк.* И.Низамов

**ЧАТА́Н-ЧОТАН** *рәв. сөйл.* Чатанлап, аксап-туксап. *Болар белән ризыкланганнан соң, Вәлиулла, балтасын култыгына кыстырып, чатан-чотан атлый-атлый, колхоз амбарлары ягына таба юнәлде.* Ф.Яхин

**ЧА́Т БАШЫ** *и.* Урамнар кисешкән урын, юл кисеше. *Берәр күзәтүче ялларгамы, яки үзеңә якынрак чат башында сагалап торыргамы?..* Ә.Еники

**ЧАТКЫ** *и.* 1) Тиз арада күренеп калган вак ут бөртеге, очкын. *Кинәт бөтен цехны җанландырып, тирә-якка көлтә-көлтә чаткылар сибеп, вагранкадан эрегән чуен ага башлый.* М.Хәсәнов. *Каршыбызда, тирә-юньгә бихисап чаткылар чәчрәтеп, чытырдый-чытырдый, учак яна.* И.Диндаров // Фотога төшергәндә камерадан күренеп алган яктылык. *Шунда ук кинога, телевизорга төшереп йөриләр, фоторепортёрларның чаткылары елт-елт кабынып китәләр, иңнәренә сары күн сумка аскан, кулларына микрофон тоткан радиокорлар делегатларның тавышларын язалар.* Г.Әпсәләмов

2) Берәр нәрсәдән чагылып ялтырап торган, җемелдәп алган кечкенә яктылык нурлары. *Бүген әзрәк суытып җибәргәнгә, кояшлы һавадан вак-вак энҗе кебек ак кар чаткылары коела.* Г.Әпсәләмов. *Аның нурлары юка боз белән капланган кар өстендә миллионлаган чаткылар уйнатып җемелди, агач ботакларында асылынып торучы озынча боз тамчыларын алтынсу кызгылт төскә манып, күзләрне иркәли.* Ф.Хуҗин

3) *күч.* Хис-кичереш, фикернең чагылышы, кечкенә, зәгыйфь билгеләре. *Аның әнә шул сизелер-сизелмәс кенә, әмма карусыз елмаюы күңелемдәге өмет чаткысын тергезеп җибәрде ---.* В.Нуруллин. *Кечкенәсенең карашында хәтта нindидер үпкә һәм шелтә чаткылары да бар шикелле иде.* В.Имамов

4) Гомумән берәр нәрсәнең беренче, сизелер-сизелмәс башлангыч билгеләре. *Бу – аның уенча, югалган матурлык. Безнең буын вәкилләрендә чаткылары гына калган матурлык.* Р.Рахман. *Хезмәттәшем һәм фикердәшем, үзендә диабет чире чаткылары сизелүгә, катгый диетага утырды.* Т.Нәҗмиев

**ЧАТКЫЛАНУ** *ф.* 1) Чаткылар чыгару; очкынлану. *Тагын берсе – янган учак, Чаткылана, яна, оча, иксезчиксез күккә китеп Бар галәмне күрә ала.* А.Нәҗми

2) *күч.* Уяну, барлыкка килү, арту. *Әмма, чемпион әфәнде, болай булгач, минем отарга ук ният-өмет чаткыланды, сак булыгыз!* М.Хуҗин

3) *күч.* Нурлану, очкынлану, ялтырау. *Күзләре чаткыланып очкын чәчте, йөрәкләре дөп-дөп типте.* Х.Камалов

**Чаткыланып китү** Кинәт чаткылану. *[Галимҗан аганың] Соргылт күзләре ачылып, чаткыланып киттеләр, йөзе яктырды.* И.Салахов. *Лейтенантның күзләре чаткыланып китте.* Х.Камалов

**Чаткыланып тору** Туктаусыз чаткылану; әле, хәзер чаткылану. *Әни борылды, күзләре зур булып ачылган иде, чыраенда нindидер ачу төсмерләре чаткыланып тора.* Ф.Садриев

**ЧАТКЫЛЫ** *с.* 1) Чаткылары күренеп торган, очкынлы. *Паровоз, чаткылы төтенен ишеп чыгара-чыгара, алга ыргыла иде.* Ә.Еники

2) *күч.* Ялтырап китә торган, нурлы. *Чаткылы күзләренең төсләрен еракатан ачыклавы кыен, әмма хуҗалары икенче рәттә утырган ханым икәнлеген сиземли нотыкчы.* Т.Галиуллин

**ЧАТЛАМА** *с. к.* **чатнама** I. *Ә бу хәл үзе кышкы чилләдә, чатлама суык заманда булган.* Г.Ибраһимов. *Яланөс тыштан сөлге белән сөртенеп керде, шушындый чатлама суыкта кар белән ышкындым, ди.* Т.Гыйззәт

**ЧАТЛАНУ** *ф.* Икегә аерылу, тармаклану. *Елга аръягындагы кара урманнар артыннан күтәрелгән кояш та, ничектер, кызарып бүртенгәнгә охшап, чатланып чыкты.* М.Хәсәнов

**ЧАТЛАП** *рәв.* 1) Тармаклап, берничә тармакка аерып. *Без, аның белән янәшә утырып, чи тиредән, унике чатлап, икебезгә ике камчы үрдек.* М.Маликова

2) Почмак ясап. *Яулыкны чатлап бәйләү*

**ЧАТЛАТЫП** *рәв. к.* **чатнатып**. *Тарихтан Рушадка «Боз өсте сугышы» эләкте – анысын чатлатып сөйләде, тик каушаудан ухо сүзен күплек санда ухи, принёс сүзен принесёл дип (янәсе, хатын-кыз булса принесла бит!) әйтеп кенә имтихан алучыны көлдерде.* М.Мәһдиев. *Уйлап та тормады бәбекәччәем, чатлатып пичәт сукты: – Дөр-рес, әткәй!* Ф.Баттал

**ЧАТЛАШ** *с.* **1.** Каршы якка кыйгачрак урнашкан. *Өйгә чатлаш кибет*

**2.** *рәв. мәгъ.* Каршы якка кыйгачрак итеп. *Китапханәгә чатлаш урнашкан бина*

**ЧАТЛЫ** *с.* 1) Тармаклы, япьле, аерчалы. *Анысы аеруча чыдам җепле, кармагы да өч чатлы, таягы да ныклы.* Ф.Баттал. *Елан ике чатлы телен уйнатып тора бирде.* Г.Гыйльманов

2) Почмаклы. *Биш чатлы йолдыз*

**ЧАТЛЫ́-БОТЛЫ** *с.* **1.** 1) Тармаклы-тармаклы, тигезле-тигезсез, аркылы-торкылы. *Хәсән, моны күреп, читкә тайпылды һәм чатлы-ботлы үскән зирекнең кәкре ботагыннан эләктерде.* А.Расих. *Зөлхәбирә күпме йоклагандыр, хәтерләми, төшендә әллә нинди әкияти гыйфритләр, тәннәрен йон баскан чатлы-ботлы шайтаннар күреп саташып, бастырылып бетте.* Ф.Абдуллин

2) *күч.* Кимчелекле; нормага буйсынмаган; начар. *Рифмалар чатлы-ботлы, шигырьдән төртеп чыгып торалар.* С.Хәким

**2.** *рәв. мәгъ.* Төрле якка каратып, тигезле-тигезсез итеп; төрле якка тырпаеп, аркылы-торкылы булып. *Көчсез кул белән чатлы-ботлы итеп язылган «әни» сүзе, кат-кат буялган булуга карамастан, һаман ап-ачык күренә иде.* Ф.Яруллин. *Казыган җирне такталар, терәүләр белән ныгытты, өй бурасы астына да чатлы-ботлы баганалар утыртып чыкты…* Г.Гыйльманов

**ЧАТЛЫК** *и.* 1) Юллар, урамнар кушылган урын, чат. *Имләгәндә шушы сүзләрне әйтәләр: --- бер, ике, өч, дүрт, биш – биштән кайтсын, биш юл чатлыгына китсен; бер, ике, өч – өчтән кайтсын, өч юл чатлыгына китсен.* К.Насыйри. *Җилнең аталары чатлыкта котыра.* Т.Нурмөхәммәтов

2) *сөйл.* Почмак. *Партизан, урман чатлыгыннан борылып, атын камчылый-камчылый, ылыслар белән түшәлгән юлдан алга чапты.* А.Расих

**ЧАТЛЫ́-ЧАТЛЫ** *с. к.* **чатлы-чотлы**. *Сварка уты шикелле тамырдай чатлы-чатлы юан ахак җепселләр кара болытны телгәләп-телгәләп үттеләр.* Ф.Садриев

**ЧАТЛЫ́-ЧОТЛЫ** *с.* Тармаклы; якякка җәелгән. *Ничек кенә җеннәре карышмасын, малайларга җиңенә чатлы-чотлы әвернә – свастика таккан офицерның боерыкларын үтәргә туры килә.* А.Тимергалин

**ЧАТМА** *и. уйг.* **1.** 1) Ялтыравыклы җепле тукыма; парча. *Алар [каеннар] нәкъ чатмадан, ак атластан киенгән төсле булып утыралар.* Г.Рәхим

2) Шуннан тегелгән кием. *Кечкенә генә түгәрәк күл, Тирәк аның эчендә, Чатма кигән, камка кигән Кызлар аның эчендә, Биленә кылыч бәйләгән Егетләр аның эчендә* (*Көзге*). Табышмак

**2.** *с. мәгъ.* Шундый тукымадан эшләнгән. *Вай, галим Әфләтун, бармы сездә кызга чатма тун?* К.Насыйри. *Инде ул мәһәргә килгән камзуллык, чатма тунлык, хәтфә, чук-чук энҗе димсең ---!* Ф.Халиди

**ЧАТМАШ** *рәв. диал.* Аркылы-торкылы

**ЧАТНАМА** I *с.* 1) Бик көчле, тынны куырып ала торган, зәмһәрир (кышкы салкын тур.). *Ә алда тагын да хәтәррәк нәрсә көтә: чатнама салкын кыш.* М.Хәсәнов. *Тышта чатнама суык.* М.Мәһдиев

2) Бик салкын. *Чатнама су*

**ЧАТНАМА** II *и.* Чатнаган җир, чатнап, сызылып киткән эз, тирән булмаган ярык. *Баскан саен, боз чатыр-чотыр килә, тирә-якка яшен укларын хәтерләткән чатнамалар тарала.* М.Яһудин

**ЧАТНАП** *рәв.* 1) Нык итеп, чатырдап. *Балавыз кебек, кайда күпме кирәк, шулчаклы сылыйсың да өстенә паяльник белән эрегән кургаш тамызасың, чатнап ябыша да куя, берни белән дә кубара алмыйсың.* Х.Камалов. *Буяуның сыйфаты шуның төсле генә булган, күрәсең: җылы әйбер куйсаң, чатнап ябыша.* Г.Рәхим

2) Кинәт; сискәндереп. *Аның башыннан, ирексездән, әгәр шундый берәр хәл булса, минем хатыным да шулкадәр еллар буе исендә тотар иде-ме икән, дигән уй чатнап узып китә.* Ә.Сафиуллин

**ЧАТНАТУ** *ф.* 1) Бәреп, басым ясап нәрсәнең дә булса өслегендә ярылып киткән эз, ярыклар барлыкка китерү. *Рамнардагы пыяланы суык чатната.* Р.Мөхәммәтшин. *Шуңа күрә мин, җәрәхәтләремне бәйләгәндә, бөтен көчемне туплап түзәргә тырышам, кычкырып җибәрмәс өчен, яңак сөякләремне чатнатырлык итеп тешләремне кыса торган идем.* Г.Галиев

2) *күч.* Какшату, нык урнашкан нәрсәнең үзгәрә башлавына сәбәпче булу. *Үзенә булган ышанычымны чатнатты*

**Чатнатып бетерү** Күп урыннан чатнату

**Чатнатып җибәрү** Кинәт чатнату; бераз чатнату. *Инкыйлаб шулай ук дини мәктәпләрнең еллар дәвамында торaташ булып каткан кадими укыту ысулларын да чатнатып җибәрде, заман таләпләренә якынайтты.* М.Әмирханов

**ЧАТНАТЫП** *рәв.* 1) Ачык итеп, курыкмыйча, кистереп. *Нәкъ шунда язылганча, чатнатып сөйләп алып киттем мин моңа.* В.Нуруллин. *Чөнки белемгә үзе атлыгып торган, көн-төн укыган талантлы, сәләтле балага чатнатып бишле куюның бер авырлыгы да юк.* С.Поварисов

2) Тиешле дәрәҗәдә. *Аларны, ягъни шприхеннарны чатнатып белмәгәнлектән, талантлы гына галимнәребезгә дә тик русча чыганаклар белән генә эш итәргә туры килә.* А.Хәсәнов

3) Сискәндереп. *Алдымда Шәйдулла абыйны күргәч, тапканнар капчыкны, дигән уй башымны чатнатып үтте.* Р.Батулла

**ЧАТНА́У** *ф.* 1) Фарфор, пыяла, боз кебек әйберләрдә ярык барлыкка килү. *Мондый чакларында тәрәзә пыялалары чатнардай булып зыңлый башлый.* Ф.Баттал. *Мин сикереп-биеп күрсәткән шәпкә алагаем зур боз кисәге чатнап урталай ярылды да, үзенә ияртеп, мине бозлы «күпер» астына алып кереп китте.* Р.Низами

2) Берәр нечкә яры, пәрдә яргалану, ертылып китү. *Кипкән иреннәре чатнап яргаланды.* Р.Батулла. *Бөреләрнең кабыгы чатнап ачыла барган саен, тирә-юньгә татлы-әчкелтем исләр тарала…* Р.Низами

3) Агач, салам һ.б.ш. янганда, бүрәнәләр туңганда шартлау кебек яңгыравык тавыш барлыкка килү. *Чатнап бүрәнә шартлаганы ишетелеп кала...* Ә.Еники

4) Кинәт шартлаудан яңгыравык тавыш барлыкка килү. *Миналар, нәкъ финнар өстенә төшеп, чатнап ярыла да башладылар.* Г.Әпсәләмов. *Кинәт яшен чатнап уйнаклый.* Ә.Гаффар

5) *күч.* Каты авырту. *Көннәр буе баш күтәрми эшләп, кичен, талчыгып киткәндә, чатнап башлар сызлый, сиздерер-сиздермәс күңел сыкрый.* Г.Хөсәенов. *Кичкә исә томау тагы да көчәя, еш һәм бик каты төчкерә – күкрәге яңгырый, авырттырып-чәнчеп ала, борыныннан өзлексез су ага, колагы чатный.* Р.Кәрами

6) *күч. сир.* Салкын булу. *Тышта һава чатный, Каеннардан карлар ишелә.* К.Сибгатуллин

◊ **Чатнап тора** Сүзгә, эшкә оста, кыю, үткен. *Әмма улы бер дә чирле ке-*

*шегә охшамаган иде, йөзләре алсу, үзе тере, чатнап тора.* Ф.Бәйрәмова. **Чатнап торган** 1) Каты, көчле, бик салкын; бик эссе, яндыра, көйдерә торган. *Алар фронтка барып төшкәндә, Карелиядә чатнап торган кыш иде инде.* Г.Әпсәләмов. *Кишәрлек башына җитеп, җилгә каршы борылгач, тузан болыты артта кала, йөзеңне чатнап торган кояш пешерсә дә, сулыш алу бераз гына җиңеләя шикелле.* Ф.Садриев; 2) Көчле, нык. *Тик кияүләр арасында – җир белән күк арасы: Мифтах һәрьяклап сау-сәламәт, чатнап торган көчле, чибәр егет иде.* З.Мәхмүди; 3) Көчле, яңгыравык. *Яшь җегет аларның кызыксынуын шундук тоеп алды, чак-чак кына каушап, җилкенеп, чатнап торган бер тавыш белән җыру әйтә-әйтә, думбрасын ныграк чиертергә тотынды.* Н.Фәттах

**Чатнап бетү** Берничә, бик күп урыннан яки тоташ чатнау. *Кибеп, чатнап беткән комлы җир өстендә тын алырга да куркып яткан Җәбир ике олы кеше арасында нинди сүз, нинди сатулашу барганын бөтенләй аңламады.* Н.Фәттах. *Коммуналканың кысан бүлмәсендә, элеккеге хуҗалардан калган, сыдырылып, чатнап беткән көзге каршына басып, үзенә таләпчән караш ташлады ---.* Р.Мирхәйдәров

**Чатнап китү** Кинәт чатнау. *Түшәмнән шыбырдап туфрак коелды, тәрәзәләр зеңгелдәп куйды, пыялаларына хәтле чатнап китте.* Ф.Бәйрәмова. *Мидхәтнең бөтен гәүдәсе кайнарланып, башы чатнап киткәндәй булды.* Р.Фәизов

**Чатнап кую** Бераз яки бер тапкыр чатнау. *Хәзер, ачлыктан булса кирәк, баш вакыт-вакыт бик каты чатнап куя.* Г.Әпсәләмов. *Башым чатнап куйды.* Ф.Баттал

**Чатнап тору** Әле, хәзер, сөйләү моментында чатнау. *Аштан олы булып булмас, тамагым да чатнап тора иде.* А.Гадел. *Аның карыны өзелеп ачты, башы да чатнап тора, зал ягындагы ризыкларның тәмле исләре дә бу якка ук керә иде.* Ф.Садриев

**Чатный башлау** Чатнарга тотыну. *Бу хакта уйлый-уйлый, Нәфисәнең башлары чатный башлады.* К.Тимбикова. *Кирпечләре чыгарып өйгәндә үк ярыла, чатный башлый.* Ф.Ярullин

**ЧА́Т-ЧАТ** *иярт.* **1.** Резин, күн һ.б.ш. өслеккә сукканда, сыгылмалы нәрсәләрне чәйнәгәндә, чабынганда яңгырап чыккан өзек-өзек тавышны белдерә. *Килеп җитәр-җитмәс, Сабир тарантастан сикереп төште, кулындагы нечкә тал чыбыгы белән күн итек кунычына чат-чат сугып алды.* Р.Батулла

**2.** *рәв. мәгъ.* Ап-ачык итеп, каушамыйча, чатнатып. *Әмма лектор – бик шомарган нәрсә, чат-чат җавап биреп бара.* Х.Камалов

**ЧА́Т-ЧАТ ИТҮ** *ф.* Курыкмыйча, чатнатып, кыю рәвештә әйтү, сөйләү. --- *абзый төшеп калганнардан түгел. Сүзе сүзгә йокмый, чат-чат итеп тора.* Т.Нәҗмиев

**ЧА́Т-ЧАТ КИЛҮ** *ф. к.* **чат-чат итү**. *Элек чат-чат килеп, кеше бер сүз әйткәнче, унны әйтеп ала торган иде ул.* В.Нуруллин. *Хатын чат-чат килде: – Син,Варрай, простой халыкны кысрыклап, нәчәлникләргә ярарга тырышасың.* Х.Камалов

**ЧА́Т-ЧОТ** *иярт. к.* **чат-чат**. *Ташларны шартлата-шартлата эссе салып, каен пиннегә белән чат-чот чабынуга ни җитә!* Ә.Моталлапов

**ЧАТЫ́Й-БОТЫЙ** *рәв.* **1.** 1) *к.* **чатый-чотый.** *– Һи-и-и, – диде Гомәр карт, чатый-ботый атлап (сапожникларның кайчан төз булганнары бар?!).* М.Мәһдиев. *Монда йөрмә, Чатый-ботый атларсың. Тәпиең зур, бакчадагы Бәрәңгене таптарсың.* Н.Әхмәдиев

2) Аркылы-торкылы китереп. *– Теләсә нишләтсен, – диде ул, кулларын чатый-ботый бутап ---.* Ф.Садриев

**2.** *с. мәгъ.* Аркылы-торкылы. *Ул куллары белән чатый-ботый хәрәкәтләр ясый-ясый сөйләп китте ---.* Ф.Садриев

**ЧАТЫ́ЙН-ЧОТЫЙН** *рәв. к.* **чатый-чотый**. *Саҗидә җиңги оеган аяклары белән чана артыннан чатыйн-чотыйн атлап, зур күн бияләйләрен, ирләр шикелле, шап-шоп бер-берсенә бәрде.* Г.Бәширов

**ЧАТЫ́Й-ЧОТЫЙ** *рәв.* Алпан-тилпән. *Камәр ике кулын ике як янтыгына ышкый-ышкый, чатый-чотый баскалап, кабалана-кабалана, ишектән чыгып китте.* Р.Төхфәтуллин

**ЧАТЫР** I *и. фар.* 1) Тире, нык, тыгыз тукыма һ.б.ш.ны җиргә кагылган озын казыкларга тарттырып корылган вакытлы торак. *Бу вакытта Хованский инде Алабуга крепосте янында, Каманың текә яры өстенә поход чатыры корып урнашкан иде.* В.Имамов. *Кояш агач башларын кызартып баеганда, урман түрендәге бер акланга килеп туктадылар, чатырлар корып, учаклар ягып җибәрделәр.* Л.Зөлкарнәй

2) Кояш яки яңгырдан саклау өчен ясалган япма, тент

**ЧАТЫР** II *кис.* Бик тиз, бик кызу. *Кызган баштан чатыр чабып, атны күбеккә батырып авылга кайтып кердем дә урам уртасында тавыш чыгардым.* М.Мәһдиев. *Әбисенә күтәрелеп карады, рөхсәт сорады бугай һәм миңа таба чатыр чапты.* М.Хуҗин

**ЧАТЫРДАП** *рәв.* Бик нык, каты итеп (ябышу, эләктерү тур.). *Хатын, тартәләргә чатырдап ябышып, кузгалып китмәкче булды.* М.Хәсәнов

**ЧАТЫРДАТУ** *ф.* 1) Чатыр-чотыр килгән тавышлар чыгару. *Сусыз җирләргә басканда бозга ябышкан табаннарын чатырдатып куптарып ала [ул].* М.Әмир

2) Көчле шартлау тавышы чыгару. *Теге кара болытлар якын ук килеп җитеп, чатырдатып яшен дә яшьнәп җибәрде.* В.Нуруллин. *Җиһангир өлгерми калды – эсэсчы эт астыннан шуып чыкты да --- Харитоновның автоматын эләктереп алды һәм бер йомгак булып бөтерелгән эт белән Харитоновка чатырдатып атып җибәрде.* Ә.Гаффар

3) *куч.* Берәр эшне бик җитез, җиңел, еш эшләү. --- *Әнәскәем, дип, бер хатына уйнап кына җавап биргән идем. Шуннан бирле чатырдата гына мәхәббәт хатларын.* В.Нуруллин

**Чатырдатып җибәрү** Кинәт чатырдату. *Тракторның нәрсәсендер борып, чатырдатып җибәрде, гүләү кабат акрынайгач, тирән сулап, уфтанып куйды.* Ә.Баян

**ЧАТЫРДАТЫП** *рәв.* 1) Көчле итеп, бик каты итеп, нык итеп. *Шулай да ул тирәндә йөзгәндә калтыранып алды, мине дүрт аягы белән дә чатырдатып кочаклады.* М.Хуҗин. *Маһинур, ирен җибәрергә теләмәгәндәй, чатырдатып җиңнәренә ябышты ---.* Р.Хәбибуллина

2) Тиешле дәрәҗәдә, дөрес, камил итеп. *Башларыбыз чатнап ярылса ярылыр, әмма ләкин җәйгә чыгуга без Цицерон, Лукреций, Вергилий әсәрләрен чатнатып укый алачакбыз!* Э.Касыймов. *Аларның сары чәчле балалары чатырдатып татарча сөйләшә иде.* Акчарлак

**ЧАТЫРДА́У** *ф.* Берәр коры, каты, нык нәрсә сынганда, ярылганда, янганда чатыр-чотыр килгән тавыш барлыкка килү. *Шул вакыт тәрәзә чатырдап чатнаган тавыш ишетелә.* Т.Миңнуллин. *Кәрим аңа кычкырмакчы булган*

*иде, кинәт чатырдаган тавыш ишетелде, һәм, боз ватылып китеп, Илнур суга чумды.* Ф.Садриев

**Чатырдап китү** Кинәт чатырдау. *Ләкин барып җитә алмады, боз янә хәтәр чатырдап китте.* Ф.Садриев. *Чатырдап китә яшен, Төшеп тауларга сылана.* А.Хәлим

**Чатырдап куюы** Бер тапкыр чатырдау

**Чатырдап тору** Даимән яки әледәнәле чатырдау; әле, хәзер чатырдау. *Урамнарда төрле якка ашыгып-ашыгып йөргән чит телләрдә сөйләшүче төрле халык, дагалы атлар, баскан саен чатырдап торган таш урам; кыңгыраулар шалтыратып чаж-чож итеп йөргән трамвай вагоннары, куркыныч тавышлар чыгарып чапкан автомобильләр, велосипедлар...* Г.Рафикый

**Чатырдый башлау** Чатырдарга тотыну. --- *Гөлйөзем әбинең мичендә пәрәмәчләр, коймаклар кызу-кызу чатырдый башлый иде.* Г.Исхакый

**ЧАТЫ́Р КИБЕТ** *и.* Өсте (түбәсе) корулы сәүдә урыны

**ЧАТЫ́Р-ПЫТЫР** *иярт.* Агач сынганда, янганда, берәр механизм каты итеп эшләп җибәргәндә тигезлетигезсез чыккан тавышларны белдерә. *Бу халәтемнән матай коткарды. Басып җибәрүем булды, аның, кабынып китеп, чатыр-пытыр эшли башлавы булды.* З.Хөснияр

**ЧАТЫРТ** *иярт.* Бер тапкыр кисәк каты, коры нәрсә сынып киткәндә, яңгыратып сукканда һ.б.ш.да чыккан өзек тавышны белдерә

**ЧАТЫ́РТ ИТҮ** *ф.* Чатырт сыман тавыш чыгару

**ЧАТЫ́Р-ЧАТЫР** *иярт.* **1.** *к.* **чатыр-чотыр.** *Казан эргәсендә ятып сөяккә әйләнгән сөянне әтәйнең иске сугым пычагы чатыр-чатыр телә башлый.* Л.Зөлкарнәй. *Чыннан да көзге боз кеше авырлыгыннан чатыр-чатыр чатный башлый, ә язгы боз кеше баскан җирдә туп-турыга ишелеп кенә төшә.* Бөгелмә авазы

**2.** *рәв. мәгъ.* Көчле итеп, бик кызу. *Чапты китте Миңлебай чатыр-чатыр.* Г.Тукай. *Шул футуристларга чатыр-чатыр кул чабып утыруы күз алдыннан бер дә китми.* И.Гази. *Кулына акча эләккәч, йөгерде чатыр-чатыр, Ашханәгә кергәч, мәхлук нинди хәйләләр корыр.* Ә.Хәсәнов

◊ **Чатыр-чатыр килү** Бик әйбәт бару. *Монда сезнең эшләрегез чатыр-чатыр килеп тора. И.Гази*

**ЧАТЫ́РЧӘЧӘКЛЕЛӘР** *и. бот.* Икеөлешле үсемлекләр классыннан ак, сирәгрәк сары, күк чәчәкләре чатыр рәвешендә төркемләп урнашкан, гадәттә күпьеллык үлән үсемлекләр семьялыгы. *Кумарин гликозидлар кубесенчә кузаклылар (бобовые), чатырчәчәкләр (зонтичные), сәдәф утлычалар (рутовые) семьялыкларына керүче үсемлекләрнең башлыча тамырларында һәм җимешләрендә туплана.* Агулы үсемлекләр

**ЧАТЫ́Р-ЧОТЫР** *иярт.* **1.** Агач, сөяк сынганда, янганда, яшен яшьнәгәндә, чәйнәгәндә һ.б.ш. очракларда чыккан өзек-өзек тавышны белдерә. *Кузгалып кына киткән идем, тагын чатыр-чотыр куакларны сындырып бара башлады.* Г.Бәширов. *Сөякләрне чәйнәп йоткач, ул авызына -- колбаса, сарымсак, суган, горчицалы ипи капты да чатыр-чотыр чәйнәргә керешә.* Ф.Садриев

**2.** *и. мәгъ. к.* **чытырман.** *Шулай булса да, сазлык ерып, тәнеңне сыдырып, чатыр-чотыр аша үтеп керүгә караганда, монда җиңелрәк: үрмәләп-шуышып кына менәсе.* К.Җәмит

**ЧАТЫ́Р-ЧОТЫР ИТҮ** *ф.* Чатыр-чотыр кебек тавышлар чыгару, чатырдау

**ЧАТЫ́Р-ЧОТЫР КИЛҮ** *ф. к.* **чатыр-чотыр итү.** *Тик учак кына ара-тирә чатыр-чотыр килеп ала да, атларның гына кыңгырау тавышлары ишетелгәләп китсәли.* Г.Бәширов. *Өшегән кулларын чатыр-чотыр килеп яна башлаган учак җылысына сузып чүгәләгән генә иде, аты никтер урынында таптанып куйды.* Ш.Шәйдуллин

**ЧАУКА** *и. диал.* **1.** 1) Куак. *Чиге җитә түзеп торуның, Тартам автоматның курогын: Суккан яшен кебек чытырдап Сибелә ут чаука артыннан.* Ф.Кәрим

2) Чыбык. --- *ана, яшь каен чаукасы кебек сыгылып, үле баласын вагон бәдрәфенә алып кереп бикләнде һәм, шашкан күзләр белән, сабыйның көйгән иреннәренә авызын куеп тын өрә башлады ---.* А.Хәлим

**2.** *с. мәгъ.* Куак рәвешендә булган, вак. *Мирхас тегеләрнең документларын эзләде, Мурзыев, чаука каеннар сындырып, носилка әзерләде.* Х.Камалов

**ЧАУКАЛЫК** *и. диал.* Куаклык. *Якында гына чаукалыклар башлана, шуның буенча түбәнгә табарак бер такыр сукмак сузыла икән.* Х.Камалов. *Ерганак-чокыр тирәләрен хәстәрләп караганнар, ярларда вак-төяк чаукалыклар калкынган.* А.Гыйләҗев

**ЧАУ-ЧАУ** *и. кыт.* Элек эре хайваннарны аулауда кулланылган зур башлы, кечкенә колаклы, шәмәхә телле, гадәттә җирән төстәге куе йонлы декоратив эт токымы. *Чау-чау асрау*

**ЧАХО́ТКА** *и. рус* Үпкә авыруы, үпкә туберкулёзы. *Ул, бичара, бик авыру икән (чахотка кимерә үзен), һәм аның сөмсерлеге дә, сүлпәнлеге дә, күзләрендәге бизгәк уты да әнә шуңардан килә икән.* Ә.Еники. *Хак булса, Даниярны, чахотка белән авырый, диләр.* М.Хәсәнов

**ЧАХО́ТКАЛЫ** *с.* Чахотка белән авыручы. *Әллә инде, көн-төн җилбуран куып йөри-йөри, бөтенләй чахоткалы кешегә әверелдеме, белмәссең.* Л.Хәмидуллин

**ЧАХОХБИ́ЛИ** *и. груз. кулин.* Кавказ халыкларында тавык итеннән төрле тәмләткечләр салып әзерләнә торган ашамлык. *Узган атнаны башкалага йомыш белән килгән кардәше, студент халкына калория кирәк, «Арагви»га барып сациви, чахохбили аша, дип, Багратның кесәсенә берничә кыштырдавык кәгазь тыгып киткән иде.* М.Юныс. *Инсаф нык борычлап итле бәрәңге пешергән, ул аны чахохбили дип атый.* М.Маликова

**ЧА́ЧА** *и. груз.* Грузиннарда йөземнән өйдә бер-ике тапкыр куып ясала торган аракы

**ЧАЧАК** *и.* Бизәү өчен тукыма читенә тотыла торган чуклар тезмәсе; *русчасы:* **бахрома**. *Ул калпакка ука чачак һәм ука чук тагалар, бик арзан тормый.* К.Насыйри. *Хәерле булсын, ука чачагы белән бер асыл күлмәк миннән булсын алайса!* Ф.Әмирхан

**ЧАЧАКЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **чачаклау**

2) Телгәләнү, тузып, җепләре чыгып чуклану. *Алар озын чәч толымнарын җилкәләренә таратканнар, тез башларына төшеп җитмәгән яшькелт-зәңгәр юка ефәк күлмәкләре итәктән чачакланып ертылган һәм таралып, бөтерелеп, кызларның йомры шома аяклары тирәсендә шуып әйләнә ---.* М.Мәһдиев

3) Таҗ яфраклары күбәю; тузгып, кабарып тору. *Кылганнар шулай ук чачакланганмыни инде?* А.Хәлим

4) *күч.* Чачак кебек телгәләнү. *Урыны-урыны белән караңгы җир тирәнлегенә киткән шомлы ярыкларга аяк убылып төшмәле, тук бодай сабагының тамырлары чачакланып өскә чыккан...* М.Галиев

**Чачаклана башлау** Чачакланырга тотыну. *Морат кара пиджагын иңбашына салып, җилбәгәй җибәргән, аягында җиңел генә ботинка, чачаклана башлаган балак очлары җирдән сөйрәлә ---.* А.Гыйләҗев

**Чачаклана төшү** Бераз чачаклану. *Бер гасыр буе буыннан буынга, кулдан кулга күчеп, бу китаплар инде шактый таушалган, читләре тузып чачаклана төшкән ---.* Казан утлары

**Чачакланып бетү** Бик нык чачаклану. *Атның сыртында киез ияр, мунчала дирбия, тезгене дә тузып, чачакланып беткән.* Р.Батулла. *Аякта чачакланып беткән чабата...* А.Хәлим

**Чачакланып калу** Ахырда чачакланган булу. *Яңа булса да, гел каз боты ясала торгач, балак очлары чачакланып калган.* Р.Рахман

**Чачакланып тору** Әле, хәзер чачакланган хәлдә булу. *Хәтердә, ул бәләкәй чакта алар авылына еш кына саилчеләр килгәли иде: сәләмә киемле, иң аркылы аскан киндер букчалы, чачакланып торган иске чабаталы, олыларга ияргән бала-чага чебиләп беткән яланаяклы.* Р.Кәрами. *Күрәсеңме, ничек кысканнар: такта араларыннан пычкы гына йөрткәннәр – такта читләрен пычкы ничек талаган, ә? Иске чабата кебек чачакланып тора.* Г.Ахунов

**ЧАЧАКЛА́П-ЧУКЛАП** *рәв.* 1) Төрлечә бизәп, бик матурайтып. *Ул чачаклап-чуклап уеп эшләгән урындыклар, камин, шкаф, өстәлләр...* Шәһри Казан

2) *куч.* Үтә ялагайланып, матур сүзләр кушып. *Якын кешегә алай чачаклап-чуклап дәшмиләр ләбаса!* М.Маликова

**ЧАЧАКЛА́У** *ф.* 1) Читенә чачаклар тоту. *Киемнәр янында баш-башларын чачаклап ясаган, матурлап төрле җепләр белән чигеп бетергән озын-озын сөлгеләр, тастымаллар эленгән, өстәл өстендә юллы-юллы кызыл ашъяулык.* Х.Хәйруллин

2) Бизәү. *Бу солтаннарны, бу чукларны, бу калфакларны кызлар нигә чәчләренә кадамый да нигә алар белән чәчләрен чачакламый икән?* А.Хәлим

**Чачаклый башлау** Чачакларга тотыну

**Чачаклап бетерү** Бик нык чачаклау; тулысынча чачаклау

**Чачаклап кую** Алдан чачаклау

**Чачаклап чыгу** Башыннан ахырына кадәр чачаклау

**ЧАЧАКЛЫ** *с.* 1) Чачак тотылган, чачаклап эшләнгән. *Пәрдә күтәрелгәндә, Гайни диванга бик киерелеп, тәкәбберләнеп утырган, кулы белән өстәл өстенә япкан чачаклы эскәтернең чачакларын бөтергәләп утыра.* Г.Камал. *Дәү эти алсу төстәге чачаклы сөлгесен иңбашына салган була, дәү әни, кояш сугудан куркып, сөлгесен башына чалма итеп урый.* Г.Әпсәләмов

2) Таҗ яфракчыклары күп булган, катмарлы. *Яратам мин чачаклы кылганнарны!* А.Хәлим

**ЧАЧАКЛЫ́-ЧУКЛЫ** *с.* 1) Чуклап эшләнгән. *Габбас мулла йортына чачаклы-чуклы киемнәре белән балкып килеп кергән яучы карчыкларның берсе, сусыз юып җилсез киптерә торганы, кендекче Сафура булып чыкты.* Г.Ахунов

2) Бизәлгән; күзгә бәрелеп тора торган. *Сезнең андый чачаклы-чуклы карават чаршавы шикелле асыл күлмәкләрегез белән кешегә көлкегә калыр хәлем юк.* Г.Камал // Аерылып тора торган. *Аларга капкан ризыклары чачаклы-чуклы булсын.* А.Тимергалин

**ЧАЧАРУ** *ф. диал.* Сүсәрү, чуклану

**Чачарып бетү Бик нык чачару.** *Тик ул инде шактый ук искергәнгә охшый: җиң очлары, кесә капкачлары чачарып беткән, бер-ике урыннан мамыгы да күренеп тора.* Г.Бәширов

**ЧАШТЫРДА́У** *ф.* Чыштыр-чоштыр килгән тавышлар чыгару. *Шунда, пырылдап, агач башыннан ябалак очып китә, куак артыннан, чаштырдап, «кылый» чыгып йөгерә, яфрак астында керпе кыштырдап йөри.* Ш.Бикчурин

**Чаштырдап тору** Әле, хәзер чаштырдау

**Чаштырдый башлау** Чаштырдарга тотыну

**ЧАШТЫРДЫК** *с.* Чаш-чош килеп торган, чаштырдый торган. *Өстендә пальто дисәң пальто, сырма дисәң сырма түгел, кыландырып теккән чаштырдык бер нәрсә шунда.* Ж.Рәхимов

**ЧАШТЫ́Р-ЧОШТЫР** *иярт.* Коры үлән, камыш, чыбык-чабык, яфрак һ.б.ш.га кагылганда, зур аяк киемен өстерәп йөргәндә, тупасрак нәрсәләр үзара ышкылганда чыккан тавышны белдерә. *Менә шуны яхшы белгән безнең кызлар, урам чирәмендә түгәрәк ясап, чаштыр-чоштыр биергә дә тотындылар, аннары барыбыз бергә «сакчылы», «әйләнбәйлән» кебек уеннарны да башлап җибәрдек.* Ә.Еники. *Галимә дусты Сәлимә кушканча эшләде: күршесенең, йокыдан торып, чаштыр-чоштыр йөрүен ишетү белән, аларга керде.* Ф.Яруллин

**ЧАШТЫ́Р-ЧОШТЫР ИТҮ** *ф.* Чаштыр-чоштыр кебек тавышлар чыгару

**ЧАШТЫ́Р-ЧОШТЫР КИЛҮ** *ф. к.* **чаштыр-чоштыр итү.** *Шактый вакыт узгач, каз чаштыр-чоштыр килә башлады.* Ф.Садриев. *Сул якта, чаштыр-чоштыр килеп, ямаулы транспортёр лентасы шуыша.* А.Тимергалин

**ЧАЯ** *с.* **1.** 1) Кешеләр белән аралашканда оялмый, тартынмый торган; үткен, тапкыр һәм кыю. *Таифә исемле бер бик чая хатын бар иде Көрнәледә.* В.Нуруллин. *Чая күрше кызы да Гыйлемдарны үтәли күрә иде бугай...* А.Тимергалин

2) Үткенлек, кыюлык чагылып, күренеп торган. *Җитмәсә, Гөлфинур, чая күзләреннән очкыннар чәчә-чәчә: «Чынмы, Рәфис, моны син әйтәсеңме соң?» – дип, малайны уттай кызартты.* А.Вергазов. – *Булмас ла! – ди Рәйхан һәм чая тавыш белән көлеп җибәрә.* Д.Каюмова

3) Телгә тапкыр, үткен сүзле. *Әмма шушы чая телле, ачык күңелле кызыкайның үз пассажирлары белән теттереп сөйләшеп җибәрәсе килә.* А.Хәсәнов

4) *сөйл.* Җитез, елдам, чарыс. *Көннәр – чаба... Себер итәгендә Мартеннары дөрли Уралның – Сыңар күзле чая трамвайлар Уртасына чыгар урамның.* Р.Низамиев

**2.** *рәв.* Тапкыр һәм кыю итеп. *Әйтәм җирле, бик чая кылана.* Г.Бәширов. *Бик чая җавап бирдең.* А.Гадел

**ЧАЯЛАНДЫРУ** *ф.* Чая итү, чаяга әйләндерү

**ЧАЯЛАНУ** *ф.* Чаяга әйләнү, чая булып китү. – *Мирсәет абый, – дип, чаяланып елмая бирде кыз.* Р.Мөхәммәдиев. *Кирәк икән, мин – беркатлы туташ, Кирәк икән, булам горур кыз. Шаярам һәм чаяланам кайчак: Я топ-модель булам, я йолдыз.* С.Әхмәтҗанова

**Чаялана бару** Торган саен чаялану

**Чаялана төшү** Бераз чаялану. *Шуның өстенә, күп йөреп, күп кеше күрә торгач, үзем дә бераз шомардым, чаялана төштем түгелме икән?* Г.Бәширов. *Ул армиядә йөргән арада калкып, үсеп киткән, чаялана төшкән Сәрияне ике ел буена сөеп, яратып йөрде егет.* Л.Хәмидуллин

**Чаяланып бетү** Бик, күзгә күренеп чаялану

**Чаяланып китү** Кинәт чаялану. *Ике-өч айдан колыныбыз зерә дә чаяланып китте.* Г.Бәширов

**ЧАЯЛЫК** *и.* Кыюлык, үткенлек; чая булу үзлеге. *Мөбарәкне – юашлыгына күрә, Бүләкне чаялыгы өчен сөя бугай ул.* Р.Батулла. *Ә чаялыгы белән ул малайларга да тартым, ахрысы.* А.Тимергалин

**ЧАЯН** *и. зоол.* 1) Үрмәкүчсыманнар классыннан җылы һәм эссе климатлы өлкәләрдә тереклек итә торган һәм корсагының койрыксыман өлешендә агулы угы булган кечкенә хайван. *Мәсәлән, мин, Әнәс Җаббаров, рәтсез һәм кирәксез мыжыкка әйләнү белән, чаян кебек үз-үземне чагып үтерәчәкмен.* Н.Гыйматдинова. *Чаяннар ауга төнлә чыга.* Биология

2) Укчы һәм Үлчәү йолдызлыклары арасында урнашкан йолдызлык атамасы; гакрәб. *Чаян йолдызлыгында Кояш ноябрьдә була.* А.Тимергалин

**ЧАЯН-ЕЛАН** *җый. и.* Һәртөрле чага торган хәшәрәтләр, чаяннар һәм еланнар; елан-чаян. *Җан-тәнемне чаян-елан чаккан көн.* Р.Гаташ

**ЧАЯ́Н УТЫ** *и. бот.* Күбаяклылар семьялыгыннан шуышма тамырчалы агулы мәңгеяшел абага; *русчасы:* **многоножка**

**ЧАЯНЧА** *и.* Чаянчалар отрядыннан буыннардан торган корсагы чаянныкыдай өскә таба бөгелеп торган, аяклары сары, корсак очы кызыл, канатлары кара таплы бөҗәк; *русчасы:* **скорпионница**

**ЧАЯРУ** *ф. диал. к.* **чаялану**

**Чаярып бетү** Бик чаяру. *Тәмам чаярып бетте Кәлинең хатыны.* Ф.Зариф

**ЧӘБӘ** *ы.* Этне куганда яки берәр нәрсәдән тыйганда кулланыла. *Татарча этне «чаба! чәбә!» дип куалар.* Н.Фәттах. *Надан кеше «маһ» дигәнгә килә, «чәбә» дигәнгә китә.* С.Поварисов

**ЧӘБӘЙ** *и. к.* **кузна**. *Тунының ике кесәсе дә бүлтәеп чыккан. Аларның эче туп-тулы чәбәй! Кузна да диләр.* З.Зәйнуллин

**ЧӘБӘЙЛЕ** *и.* Балаларның җәй көне ачык һавада сарык, кәҗә, ат, сыер кебек хайваннарның ашык сөяген, бәкәл сөяген кулланып уйный торган уены. *Сугыш, кычкырыш чәбәйле уйнап беткәннән соң гына булырга мөмкин.* З.Зәйнуллин

**ЧӘБӘК** *и.* 1) Ике кулны учлары белән бер-берсенә сугу хәрәкәте. *Чәбәк ике кулдан чыга.* Әйтем

2) *к.* **чәбәк-чәбәк**. *Юрүзәндә кояш чәбәк уйный, Каеннарда моңнар адашкан.* Ф.Галиева

**ЧӘБӘ́К ИТҮ** *ф.* 1) Уч белән ниндидер йомшак әйбергә сугу. *Аннан кытыршы кулым белән артыңа берне чәбәк иткән идем, кычкырып җылап җибәрдең...* А.Гыйләҗев

2) Ике кулны учлары белән бер-берсенә сугу. *Иң әүвәле әнкәй чәбәк итте – Анның чәбәгенә биедек.* Р.Ягъфәров

**ЧӘБӘКЛӘ́Ү** *ф.* 1) Кулның учы яки гомумән йомшак нәрсә белән берәр нәрсәгә сугу, суккалау. – *Моннан ары су белән шаяру бетте! – диде Рәүф, юеш беләкләрен чәбәкләп.* А.Тимергалин. *Карчыклар аны сихерли башладылар: битенә, шәрә тәненә ниндидер ак, кара ташлар белән сызыклар сыздылар, өстенә көл сиптеләр, әллә нинди үләннәр белән йөзен чәбәкләделәр...* Г.Гыйльманов

2) Кемне яки нәрсәне дә булса хуплау йөзеннән аңа уч белән сугу, суккалап алу; учны учка сугу, кул чабу, алкышлау. *Балалар кул чәбәкли-чәбәкли тәгәрәп көлделәр.* А.Гыйләҗев

3) Чәбәкле уенындагы кебек бер-берсенең учларына сугып алу. *Аягын аякка бәреп җылынырга маташкан Нәкыя белән Фаягөл балаларча кулларын чәбәкләде.* А.Әхмәтгалиева

**Чәбәкләп алу** Бераз чәбәкләү. *Клара хуш ис бөркеп торган йомшак куллары белән ике битемнән чәбәкләп алды.* А.Хәсәнов. *Балаларча кул чәбәкләп алган Әминә тагын да балкып, яктырып китте.* Г.Гыйльманов

**Чәбәкләп кую** Бер тапкыр чәбәкләү. *Кинәт Зөһрәнең зиһенендә ниндидер якты, бәхетле нурланыш барлыкка килде, ул, үзенең ачышыннан очынып китеп, кулларын чәбәкләп куйды.* Г.Гыйльманов

**Чәбәкләп тору** Гел чәбәкләү; берникадәр вакыт чәбәкләү; хәзерге моментта чәбәкләү. *Азат, Ситидан аермалы буларак, күбәләктәй бөтерелүче биючәнең бер алдына, бер артына төшеп, дымлы күзләрен кысып, шат елмаеп кулларын чәбәкләп торды.* А.Нәҗми

**Чәбәкли башлау** Чәбәкләргә тотыну. *Менә Майкы би йөзен югарыга чөйде. Миек чылгыйлары яңак өсләренә кайтарылып чәбәкли башлады.* В.Имамов

**ЧӘБӘКЛЕ** *и.* Кара-каршы торган ике кешенең бер-берсенең учларына сугып уйный торган уены. *Әле мин булмаганда, Әле син булмаганда, Озынколак куяннар Качышлы уйнаганнар, Әбәкле уйнаганнар, Чәбәкле уйнаганнар...* Л.Лерон

**ЧӘБӘ́К УЕНЫ** *и. к.* **чәбәкле**

**ЧӘБӘ́К-ЧӘБӘК** *и. к.* **чәбәкле**. *Яшьләр – җырлы-биюле түгәрәк уен, кыз балалар кырыйдарак чәбәк-чәбәк уйныйлар.* Г.Галиева

**ЧӘБӘК-ЧӘБӘК ИТҮ** *ф. к.* **чәбәк итү**. *Тирә-юньдә кошлар сайрый, кояш нурлары җемелди, кызлар көлә, сабыйлар чәбәк-чәбәк итә.* Р.Камал

**ЧӘБӘЛӘНДЕРҮ** *ф.* 1) Чуалту, тәртипсез хәлгә китерү (җеп, чәч һ.б.ш.ны). *[Мирсәет абый:] – Ипләбрәк, егетләр, чәбәләндереп бирмәгез печәнне, саклар өчен өябез бит аны, ничек ята, шулай бирегез, – дип кисәтә.* Г.Тавлин

2) Кулларны, аякларны, канатларны төрле якка аткалап, еш-еш, кискен хәрәкәтләр ясау. *Мәрьям ыңгыраша. Аякларын чәбәләндерә.* Ф.Яруллин. *Сәүбән «канат белән» туды. Кулларын җилпеп, чәбәләндереп туган балаларга шулай диләр.* Г.Гыйльманов

3) *күч.* Эзлеклелеген, бәйләнешен югалту, чуалту (фикер сөреше, уйның һ.б.ш.ның). *Озакламый алар, әлбәттә, янә очрашачак, кайнар хисләрен янә чәбәләндерәчәк...* Э.Касыймов. – *Мужыт, бүтән кайтышлар да юктыр, – диде абыйсы һәм кинәт кенә сүз йомгагын чәбәләндерде.* Н.Гыйматдинова

**Чәбәләндерә башлау** Чәбәләндерергә тотыну. *Сораучы җавап бирүчене үз сүзләре белән чәбәләндерә башлый.* Ф.Баттал

**Чәбәләндереп алу** Кыска гына вакытка чәбәләндерү. *Рабига кулларын чәбәләндереп алды.* Ф.Сафин

**Чәбәләндереп бетерү** Тәмам чәбәләндерү. *Алар бит, паразитлар, кырмавык кебек: чәчкә бер ябышса, чәбәләндереп бетерә.* Җ.Юныс

**ЧӘБӘЛӘНҮ** *ф.* 1) Чуалу, тәртипсез хәлгә килү (җеп, чәч һ.б.ш.). *Кайсы алтын савытларга салынган сигара, кайсы көмеш тартмалардан бармак юанлыгы калын папирос, кайсы атлас янчыклардан мунчала төсле чәбәләнеп беткән тәмәке чыгарып суздылар, ди, батыр егеткә.* А.Алиш. *Мин, тәрәзә кашагасына сөялеп, Фәхри абзыйның эчкә баткан күзләренә, чәбәләнгән сакалына карап торам.* А.Гыйләҗев

2) Еш-еш, төрле якларга кискен хәрәкәтләр ясау. *Зәки тәрәзәләрне ныклап яба, чәбәләнеп корт куа.* А.Гыйләҗев

3) Ашык-пошык һәм тәртипсез рәвештә нидер эшләү, ыгы-зыгы килү. *Гел ашыгып, кабаланып, чәбәләнеп яшәү йөрәккә сигнал биргән.* А.Гыйләҗев. *Бал*

*корты тәрәзә пыяласында чәбәләнгән чакта, саклык белән генә аның өстенә буш тартманы каплыйм.* А.Хәсәнов. *Ишек төбендә чәбәләнгән Нәфисәне ничек кенә тынычландырырга тырышса да, булдыра алмады.* Г.Гыйльманов

4) *күч.* Эзлеклелеге бозылу, бәйләнеше югалу, чуалу (фикер сөреше һ.б.ш.ның). *Уй җепләре төрле якларга китеп чәбәләнделәр.* А.Гыйләҗев. *Аның уйлары оя аерганда тузгыган умарта күчедәй тузгый, чәбәләнә иде.* А.Вергазов

**Чәбәләнә башлау** Чәбәләнергә тотыну. *Хатын чәбәләнә башлады.* З.Хөснияр. *Габдулла җан ачысы белән кычкыра, чәбәләнә башлады.* Р.Батулла

**Чәбәләнеп бетү** Тәмам чәбәләнү. *Тамырлар бер-берсе белән тоташып, чәбәләнеп беткәннәр иде.* А.Гыйләҗев. *Гүя очын дошман эзләп тапмасын дип, Чәбәләнеп беткән безнең тамырлар.* Р.Зәйдулла

**Чәбәләнеп китү** Билгеле моменттан башлап чәбәләнү. *Әкрен генә күз кабаклары ябыла башлады, йокы басты – көн буена ат өстендә бару үзенекен итте: уйлар җебе чәбәләнеп китте.* М.Хәбибуллин

**Чәбәләнеп кую** Кинәт яки бераз чәбәләнү. *Ир белән хатын корт чаккандай чәбәләнеп куйдылар.* Р.Сибат

**Чәбәләнеп тору** Даими чәбәләнү; берникадәр вакыт чәбәләнү. *[Виталик] Җил тегермәненә охшап китә – куллары, сүз куәсенә иярәм дип, гел бербереен куышып, әйләнгәләп, чәбәләнеп тора.* М.Галиев. *Шул сүзне әйткәндә, Вәкил чәбәләнеп торган балыкның эчен ярып җибәрде.* М.Хәбибуллин

**Чәбәләнеп яту** *сөйл. к.* **чәбәләнеп тору**. *Ул һаман да борчыла, чөнки ул һаман да заманасы карынында чәбәләнеп ята.* Р.Харис. *Күзгә артык бәрелеп тормаган бу караңгы сукмак очында, күңелләрне әсир итәрлек серле-сихерле йомгак булып, нур балкышы чәбәләнеп ята иде.* Г.Гыйльманов

**ЧӘБЕ** I *и. диал.* Чыбыкны яткырып үргән читән, аркылы читән. *Язгы ташу чәбесен агызып алып киткән, тешсез авызын ерып утыручы буадагы берән-сәрән калган казык кебек корган агач ботаклары да ыржаеп тормас.* Р.Газиз. *Чәбе үреп, язын бәрәңге дә утыртып куйганнар иде шул нигезгә.* Р.Мөхәммәдиев

**ЧӘБЕ** II *и. рус махс.* Сугыла торган буй җеп буталмыйча аерылып торсын өчен, аның арасына көредән соң куела торган чыбык, таякчык. *Шул күлмәкнең ике ягыннан чәбе таякларыдай шәрәләнгән калак сөякләре төртеп тора.* Р.Мөхәммәдиев. *Чәбе агачы. Чәбе чыбыгы*

**ЧӘБЕГҮ** *ф. диал.* Сөрлегү, аву, егылып чуалып бетү (иген, үлән һ.б.ш. тур.). *Җилле яңгырдан соң игеннәр чәбеккән*

**ЧӘБЕРЧЕК** *с.* Кош басып утыргандa бала чыкмыйча бозылган (йомырка тур.). *Ул чәберчек күкәй юкса былтыр оя өчен мая булып калган.* Ә.Рәшит. *Тагын чүт кенә түзим, менә тиздән балаларым да чыгып җитәрләр дип, көн-төн кузгалмый утыра торгач, сыерчыгыбыз ачлыктан, ялгызлыктан чәберчек йомыркалары өстендә җан биргән.* А.Хәсәнов

**ЧӘБЕРЧЕКЛӘНҮ** *ф.* Бозылу, чәберчеккә әйләнү (йомырка тур.). *[Җиһанша:] Гөлҗамал әби, бу йомырканы ишан хәзрәт алмас – чәберчекләнгән, садаканы китергәндә, карап китерергә кирәк.* К.Тинчурин

**ЧӘБЕРЧЕКЛЕК** *и.* Чәберчек булу, бозылган булу

**ЧӘЕР** *и.* Ылыслы агачларның һәм кайбер башка үсемлекләрнең һавага бүленеп чыкканда ката торган ябышкак исле куе сыекча; агач сумаласы. *Яңа гына яфрак ярган тупыл агачларыннан әле һаман язгы ис – чәер исе килеп тора.* Г.Рәхим. *Бу юлысы ул нарат чәере исе аңкыган яңа өйләр каршында тукталмады.* Н.Гыйматдинова

◊ **Чәер кебек (төсле) ябышу** Кешегә бәйләнү, йөдәтү. *Шул кушамат Ахуновка чәер кебек ябышты.* Т.Галиуллин. *Аксолтанов ят егетнең чәер төсле ябышуын өнәмәгәнлеген сиздерсә дә, Тураев әңгәмәне кырт кисмәде.* Т.Әйди. **Чәер чәйнәү** Юк-бар гайбәт сөйләү; чүбек чәйнәү. *– Мәнә нишлиләр бит, ә? – дип, тыр-тыр чәер чәйни иде озын буйлы ябык хатын.* Ф.Яхин

**ЧӘЕРЛӘНҮ** *ф.* Чәергә әверлү яки чәер шикелле үзле, ябышучан булып китү. *Базарга килеп кергәндә, җылы яңгырдан соң, бөркү һаваны пешергән рәхимсез кояш астында сыер түшкәсе пешегеп, симез урыннары чәерләнеп, итләч төше каралып, ит дигәнең җирәнгеч үләксәгә әверелгән иде.* К.Кәримов

**ЧӘЕРЛЕ** *с.* Чәере булган. *Чәерле агачлар*

**ЧӘЙ** *и. кыт.* 1) *бот.* Чәйчәләр семьялыгыннан тропик һәм субтропик зонада үсә, культуралы төрләре эфир мае алу, яфрагын эчемлек өчен әзерләү йөзеннән махсус игелә торган мәңгеяшел агач яки куак. *Күрдем мин чәй үскәнне, Кайнарланып пешкәнне.* Ш.Галиев. *Халык монда чәй үстерү белән шөгыльләнә.* Безнең гәҗит

2) Шул үсемлекнең киптереп махсус эшкәртелгән, хуш исле эчемлек әзерләү өчен кулланыла торган яфраклары. *Икенче юлы, килеңнең чәйнеккә кашыклап-кашыклап чәй яфрагы тутырганын күреп, авыз ачкан кайнана шунда ук «ник әйттем» көненә төште.* А.Әхмәтгалиева. *Зөһрә, авыл фельдшеры, күреп калып, беренче ярдәм күрсәтеп, әҗәл тырнагыннан алып калды. Шул хәлдән соң, күршесе киңәшен тотып, яшел һәм бөртекле чәйләр генә куллана башлады.* А.Хәйретдинова

3) Эшкәртелгән шундый яфракларны кайнар суда пешереп әзерләнгән хуш исле эчемлек. *Эшчеләрнең күбесе чәй алып кереп эчәргә утырдылар.* А.Алиш. *Алар корыдан гына чәй эчтеләр.* А.Хәлим

4) *сөйл.* Шундый эчемлекне эчү гамәле; гомумән шуның белән бергә барган очрашу, кечкенә мәҗлес. *Берәр көн үткәч, туган-тумачадан берничә хатын-кызны, Зөһрә белән Сарәнең сабак иптәшләреннән берничәсен Зөһрәләр өенә чәйгә чакырдылар* Г.Рәхим. *Бүген әби үзләрен чәйгә чакырды.* А.Хәйретдинова // Гомумән мәҗлес, аш

5) Шифалы эчемлек пешереп әзерләү өчен хезмәт итә торган кипкән үләннәр, яфраклар, тамырлар һ.б.ш. *Хан үләне чәе киптерү*

6) Шундый үләннәрдән, яфраклардан һ.б.ш.дан дәмләп әзерләнә торган эчемлек. *Менә хәзер без иртәнге җиләк чәйдән соң мөнәҗҗим Мәгъсүм бине Габдулла хәзрәтнең эшкә килгәнен көтеп утырабыз.* А.Тимергалин

◊ **Чәегез тәмле булсын!** Чәй эчеп утыручыларга яхшы теләкләр белдерү йөзеннән әйтелә торган сәламләү. *[Петро:] Чәйләрегез тәмле булсын!* З.Хәким. **Чәеннән кала күренү** Бик сыек чәй турында. **Чәеннән Мәскәү күренү** *к.* **чәеннән кала күренү**. *Ә аның эчә торган чәеннән Мәскәү күренеп тора иде.* Ф.Баттал

**ЧӘ́Й АГАЧЫ** *и. бот.* Миртчалар семьялыгыннан эфир майларына бай, йөнтәс ак чәчәкле, тропикларда үсә торган мәңгеяшел агач. *Җылы суга ун тамчы чәй агачы мае тамызып та ванна ясый аласыз.* Шәһри Казан

**ЧӘ́Й АШЫ** *и.* 1) Өченче аш янына, гадәттә, камырдан әзерләнгән татлы ашамлык. *Татарның чәй ашы дип, үзбәкләргә күрсәтерием мин аны*. Г.Галиева. *Ул килеп кергәндә, килен әле чәй ашы пешерергә кузгалып, камыр басып кына маташа иде*. Л.Ибраһимова

2) *диал.* Кош теле

3) *диал.* Әче камырдан пешерелә торган вак күмәч төре. *Тиз генә чәй ашы пешереп алу*

**ЧӘ́Й ГӨМБӘСЕ** *и.* Шикәр салып эретелгән сыек чәйдә чүпрә гөмбәсе белән бактерияләр симбиозы ярдәмендә барлыкка килгән катлы-катлы элпәләрдән гыйбарәт калын лайлалы организм; шуның тереклек эшчәнлеге нәтиҗәсе булган әчкелтем эчемлек. *Уйларның очына чыгу өчен, ул кат-кат урыныннан торды, әчкелтем-баллы чәй гөмбәсе эчте*. А.Мушинский

**ЧӘЙГҮН** *и. кыт. диал. к.* **чәйнек**. *Чыксам, калай капкачын сикерткәләп, дөбер-шатыр чәйгүн кайнап утыра*. Н.Фәттах. *Гыйльманов, фильмны карый-карый, чәйгүннән стаканга чәй сала*. З.Хәким

**ЧӘЙДӘШ** *и.* Кем белән дә булса бер чәй табынында бергә булган кеше. *Берничә гасырлар безнең милләт алар илә казандаш һәм чәйдәш булып, барчасы бергә, ачлы-туклы гына булса да, тыныч кына, тату гына гомер иткәннәр*. Г.Тукай. *Ольга, чынмы бу дигәндәй, үз колакларына үзе ышанмыйча көлеп үк җибәрде, ә чәйдәше үзе дә, әйе, үзе дә, кеткет көлеп, аны көлүдән тыйды*. Р.Сибат

**ЧӘ́Й КАШЫГЫ** *и. к.* **бал кашыгы**. *Карчык нәрсәгәдер өстәлгә бер чәй кашыгы китереп куйды*. Ш.Камал. *Сырлы-сырлы бәллүр ваза. Чәй кашыгы белән суксаң да, тырнак очы белән чиртсәң дә чың итеп тора*. З.Хөснияр

**ЧӘЙЛӘ́Ү** *ф. сөйл.* 1) Чәй эчү. *Иркенләп чәйләделәр*

2) *күч.* Әз-мәз ашап алу, җиңелчә капкалау. *Вилданның да хәлләре шәптән түгел: бәрәңгесе бетеп килә, бүтән ризык инде күптән юк. Гармунын күтәреп авылдан авылга йөри, әрсезләнми, чакырсалар – кереп чәйли, кулга биргәннән алмый, ашка-чәйгә икенче тапкыр дәшсәләр, рәхмәтен әйтеп баш тарта, артыгын кыстап та тормыйлар*. М.Хуҗин // Гомумән ашау

**Чәйләп алу** Бераз чәйләү. *Чәйдән соң алар байтак кына урдылар да тагын чәйләп алдылар*. Г.Рәфикый. *Ул арада Яхия карт урман чәен өлгертеп, улларын чәйләп алырга чакырды*. А.Хәйретдинова

**Чәйләп тору** Даими яки еш кына чәйләү; хәзерге моментта чәйләү, билгеле вакыт чәйләү. *[Бикбулат:] Чәйләп үк тормам, өйдән ныгытып чыктым*. А.Гыйләҗев. *Озак йөреп арыган булгандыр, чәйләп тә тормады, башы мендәргә тигәч үк изрәп китте*. М.Рәфыйков

**Чәйләп утыру** *сөйл. к.* **чәйләп тору**. *Хадим чыгып: «Рөхсәт, рәхим итегез», – дигәч, Габдденнәсыйр әфәнде хуҗалар чәйләп утырган бүлмәгә керде*. З.Бигиев. *Исмәгыйльләр бүлмәсенә барып кергәндә, улы белән Сафа бергә чәйләп утыралар иде*. М.Галәү. *Әти белән Гәрәй җизни ак өйдә чәйләп утыралар*. Г.Афзал

**Чәйли башлау** Чәйләргә тотыну. *Хәмит чәйли башлады*. Ф.Яхин

**ЧӘЙЛЕК** *и.* Берәр төрле вак хезмәт күрсәтү өчен бирелә торган акчаның тиешеннән артыграк өлеше; бәхшиш. *Өченче номерда тора торган кеше, кибеткә бер кадак алма алырга җибәрсә дә, чәйлек бирә*. Г.Камал. *Киткән вакытта швейцарга өч сум чәйлек биреп калдырдым*. З.Бигиев

**ЧӘЙНӘВЕК** *и. к.* **күшәм**

**ЧӘЙНӘВЕЧЛӘР** *и. биол. күпл.* Буынтыгаяклы хайваннарның өске алгы казналыклары; *русчасы:* **жвалы**

**ЧӘЙНӘКЛӘ́Ү** *ф.* 1) Чәйнәп өзгәләү, күп тапкыр чәйнәү, чәйнәп бетерү

2) *күч. к.* **чәйнәү** (*7 мәгъ.*). *Кайтып керсәм, мине чәйнәкләргә тотына*. А.Гыйләҗев

**ЧӘЙНӘЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **чәйнәү**. *Әйтерсең ул чәйнәлмәгән икмәк катысын азапланып-тинтерәп йотып җибәрә иде*. А.Вергазов. *Илгизәр, гадәттәгечә, башын аска иеп, чәйнәлгән тырнакларын чокып, тагын озак кына берни эндәшми басып торды*. Л.Ибраһим-Вәлиди

2) *күч.* Кемнең дә булса гайбәте, яманаты сатылу. *Әдилә ханым бу номерга иптәш хатыннары белән еш йөри, һәм, Казанның бар гайбәте шунда чәйнәлә-чәйнәлә тәмам мунчалага әйләнгәннең соңында, юылып, чистарынып, шулардан арынып чыга иде алар*. З.Хөснияр

3) *күч.* Бер үк нәрсә турында озак һәм ялыктыргыч итеп кабат-кабат сөйләнү. *Шәкерт кузгалышы элек телләрдә бик нык чәйнәлгән иде*. Г.Ибраһимов. *Күп чәйнәлгән сюжетка нигезләнгән, шаблон булып киткән һәм үгет-нәсыйхәтләр сөйләп йөрүче персонажлардан торган әсәрләр укучыга, тыңлаучыга чын нәфасәти ләззәт бирә алмыйлар*. К.Гыйззәтов

**Чәйнәлә башлау** Чәйләнергә тотыну. *Кендек, дип, бик күп чәйнәлә башлагач кына, алар моны хәтерләп сөйлиләр*. Г.Ибраһимов

**Чәйнәлеп бетү** Тәмам чәйнәлү. *Балалы йортта, бала искеләре белән бергә, бала рәсемнәре, альбомнар, төсле журналлар, тышы купкан, сызылып, ертылып, чәйнәлеп беткән китаплар чыга*. Г.Гыйльманов. *Сәрхуш масаеп кына каршыбызга килеп басты да авызындагы чәйнәлеп беткән «Беломор» төпчеген Иблиснең аяк астына төкерде*. З.Мәхмүди

**Чәйнәлеп тору** Бик еш чәйнәлү; хәзерге вакытта чәйнәлү. *[Шәйфи:] Телефоннан район үзәген дә җыя алмаган башың белән чәйнәлеп торма ичмаса!* З.Мәхмүди

**ЧӘЙНӘТҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **чәйнәү**. *Бугазын эттән чәйнәтәсе нәрсә, ансат кына бурычтан котылмакчы була икән...* Ф.Яруллин. *Каравылчылар йоклап китмәсен өчен, аларга [алтын кошларга] сагыз чәйнәтәләр*. Татар халык әкияте

2) *күч.* Кемнең дә булса гайбәтен, яманатын саттыру. *Кеше үлем алдында булган, үлә башлаган, ә сез, бәладән тартып аласы урынына, гайбәт чәйнәтеп, аңа кабер казыгансыз*. Г.Кутуй

**ЧӘЙНӘ́Ү** *ф.* 1) Ашамлыкны яки берәр нәрсәне, авызга алып, тел хәрәкәтләре һәм тешләр белән ваклау, изү. *Ашыкмыйча әйбәтләп чәйнәп ашагыз*. Г.Галиева

2) Нәрсәне дә булса тешләр белән бик каты кысып өзгәләү, ботарлау, өзеп чыгару. *Икенче бер вакытта диңгезчеләр зур соры бүрегә тап булдылар. Ул сап-сары болан бозавын ботарлап, аның бугазын чәйни иде*. Г.Әпсәләмов. *Теге чакта сез муенга бәйләп калдырган бау кисәген сезнең арттан ук чәйнәп өздем*. А.Хәсәнов

3) Тешләр белән эләктереп алып кыскалау. *Гәрәй абзый, вак-вак атлап, миләш янына килде, кансыз иреннәрен үҗәтләнеп чәйни-чәйни, кәүсәсен арыбире эткәләп азапланды*. А.Тимергалин. *Таһир әйтер сүз тапмый, иренен чәйни*. А.Хәсәнов. *Гомерендә беренче кат, ахры, җырләр төя-төя, иреннәрен чәйнәп үкседе ул...* В.Имамов

4) Авызда йотмыйча тотып, тешләр белән кыса-кыса әвәләү. *Кайсы кырын ятып сагыз чәйни, кайсы тәрәшле та-*

*рагы белән шытыр-шытыр чәч тарый.* А.Гыйләҗев. *Гөлхәбирә алдагы буш урындыкка киерелеп утырган да лачлоч нарат сагызы чәйни.* А.Хәсәнов

5) *күч.* Кемнең дә булса гайбәтен, яманатын сату; аның артында начар сөйләү. *Клавдия Сергеевна сезне кем беләндер театрга барган өчен чәйни үк.* Г.Әпсәләмов. *Хәзер синең гайбәтеңне чәйнәп йөрүләре дә әнәтерә шул синнән көнләшүдән генә бит ул.* Г.Галиева

6) *күч.* Бер үк нәрсә турында озак һәм ялыктыргыч итеп кабат-кабат сөйләү. *Сүз чәйнәп туйдылар.* Г.Афзал

7) *күч.* Ялыктырып туктаусыз шелтәләү, тиргәү, сүгү

◊ **Чәйнәп салу** 1) Нәрсәне дә булса бик җентекләп аңлату, аңлатып төшендерү. *Барысын да чәйнәп салдым, аңлагандыр*; 2) Нәрсәнедер табып, булдырып, әзер көе кемгәдер бирү, үзенә эш калдырмау. *Әрәмтамак булып тик утырма, авызыңа чәйнәп салганны да көтмә!* Г.Бәширов. **Чәйнәп бирү** *к.* **чәйнәп салу**. *Алар көтә чәйнәпчәйнәп биргәнне.* Л.Шагыйрьҗан

**Чәйнәп алу** Бераз чәйнәү. *Башта бу темага яшьләр тормышындагы «соңгы хәбәрләр»не чәйнәп алудан керешеп киткән идек.* З.Мифтахов

**Чәйнәп бетерү** Барысын да чәйнәү. *Сабит тыелгысыз, ач хис белән ими башларын тешләп, чәйнәп бетерде.* А.Гыйләҗев

**Чәйнәп йөрү** Һәрвакыт чәйнәү. *Авыл малай-шалайлары, кыз-кыркыннар гына түгел, өлкәннәр дә Бибкәй сагызын чәйнәп йөрде.* А.Фәләх. *Тимучин гына Бөртекбикә тирмәсенә атналар буена кереп карамады, кара көеп һәм урт чәйнәп йөрде.* В.Имамов

**Чәйнәп карау** Тикшерү өчен, татып карау өчен чәйнәү. *Язның иң беренче тал бөресен Килде минем чәйнәп карыйсым...* А.Хәлим

**Чәйнәп тору** Һаман, гел чәйнәү; әле, хәзер чәйнәү; билгеле вакыт чәйнәү. *Биленә озын кылыч таккан бер кызыл-армеец башта безнең янга авызлыгын чәйнәп торган кара айгыр алып килде.* А.Хәсәнов. *Кадыйров һаман бер балык башын чәйнәп торды да китеп барды.* А.Гыйләҗев

**Чәйнәп утыру** *сөйл. к.* **чәйнәп тору**. *Бервакыт дустым белән хатын-кызны чәйнәп утырдык.* З.Мәхмүди

**Чәйни башлау** Чәйнәргә тотыну. *Энем, чыраен сытып, борыч кузагы чәйни башлады.* Аманулла

**Чәйни бирү** Бернигә карамый һаман чәйнәүне дәвам итү. *Ә дошман телләр чәйни бирәләр.* Г.Ибраһимов

**ЧӘЙНӘШҮ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **чәйнәү**. *Көн саен кабинетына ике-өч тапкыр кереп чыксаң, киңәш-ярдәм сорасаң, башкаларны чәйнәшсәң, ул сине күрми дә башлаячак.* И.Нәбиуллина

2) Бер-берсен тешләү. *Бер сөяккә унлап эт бар, чәйнәшәләр даулашып.* Г.Тукай. *Алар, туганкаем, иң хәтәр ерткычлар кебек үзара талашалар, бер-берсенең бугазын чәйнәшәләр...* М.Хәсәнов

3) *күч.* Тиргәшү, әрләшү, телләшү, талашу, ызгышу

**Чәйнәшә башлау** Чәйнәшергә тотыну. *Көтүдә бердәмлек югалган чакта хайваннар үзара чәйнәшә башлыйлар.* З.Мәхмүди

**Чәйнәшеп бетү** Тәмам чәйнәшү. *Бер йорт эчендә яшиләр, алар урынында башкалар булса, чәйнәшеп бетәрләр иде.* Ф.Яхин

**Чәйнәшеп йөрү** Гел, һәрвакыт чәйнәшү. *Ә беркөнне Нәфисә кинәт үзгәрде: берәр сәгать урамда чәйнәшеп йөргәннән соң, туган йортына кереп, әнкәсенең күкрәгенә капланып, сулкылдап-сулкылдап еларга кереште.* Г.Гыйльманов

**ЧӘЙНЕК** *и. рус* Чәй пешерү һәм су кайнату өчен кулланыла торган тоткалы һәм борынлы савыт. *Бүлмәнең тузаннары да сөртелмәгән әле, табынга куярга аш-су да юк әле, кухняда сызгыра-сызгыра чәйнек кайный, ә алар бииләр дә бииләр.* Г.Әпсәләмов. *Керосинка өстендә борыны китек яшел чәйнек кайнап утыра.* А.Хәсәнов

**ЧӘЙНИ** *и. рус к.* **чәйханә**. *Эшләре ашыгычрак булганда, дуслар, базарда гына очрашып, бергәләп чәйнигә кереп чыгалар.* М.Әмир. *Хуҗасы базар каршындагы чәйнигә «җылынып» чыгар өчен кереп китә, ә аты аның, җиргә ташлаган бүрек хәтле генә печәнгә башын иеп, күзен йомып, тик кенә тора да тора.* Ә.Еники

**ЧӘЙ РОЗАСЫ** *и. бот.* Хуш исле чәй исен хәтерләтә торган ак, алсу, сары яки кызгылт сары чәчәкле роза төре. *Көч-хәл белән өч чәй розасы җыештырып, шуны үтә күренмәле полиэтиленга төрделәр.* Ахир

**ЧӘЙХАНӘ** *и.* Чәй эчәргә һәм ашарга мөмкин булган, гадәттә Көнчыгыш илләрендәге яки шундый стильдәге җәмәгать туклану урыны. *Чәйханә халык белән, зур ак чәйнекле өстәлләр белән, тәмәке төтене белән тулы иде.* Г.Ибраһимов. *Хәмзә хаҗи мөсафирханәсенең аскы катында чәйханә урнашкан иде.* М.Галәү

**ЧӘЙХАНӘЧЕ** *и.* Чәйханә тотучы, чәйханә хуҗасы. *Чәйханәче дә озак көттермәде: җәһәт кенә сөтле кайнар чәй, бер тәлинкә кетердәп торган коймак китереп куйды.* З.Мәхмүди. *Ишек катындагы өстәл янында ике ир кеше чәйханәче белән исәп-хисап өзеп маташа.* Р.Батулла

**ЧӘЙХУР** *и. фар. сөйл.* Чәй эчәргә яратучы. *[Фидая] Безнең нәсел чәй ярата, әби дә авылда дан тоткан чәйхур иде.* М.Маликова

**ЧӘЙХУРЛЫК** *и. сөйл.* Чәй ярату сыйфаты, күп чәй эчү гадәте. *Ләкин автор бу ишаннарның чәй турында кире сүзенә караганда, аларның үзләренең чәйхурлыгын белепме, ничектер, үзе дә икеләнүгә төшә кебек: чәй ул хәләл дә, хәрам да түгел, эчкәнгә – гөнаһы, эчмәгәнгә савабы юк, дигәндәй була.* Г.Хөсәенов

**ЧӘ́ЙЧӘЛӘР** *и. күпл. бот.* Чәй куагы һ.б. кайбер мәңгеяшел үсемлекләрне берләштергән семьялык

**ЧӘЙЧЕ** *и.* 1) Чәй үстерүче, чәйчелек белән шөгыльләнүче. *Тәҗрибәле чәйчеләр көненә 10 килограммнан артык яфрак җыя*

2) Чәй белән сәүдә итүче, чәй сәүдәгәре. *Чәйчеләр аны чәй белән сыйлыйлар.* Шәһри Казан

3) *сөйл. к.* **чәйхур**

**ЧӘЙЧЕЛЕК** *и.* Авыл хуҗалыгының бер тармагы буларак чәй үстерү, чәй җитештерү. *Чәйчелек колхозлары. Чәйчелек алга киткән илләр. Азәрбайҗанда чәйчелек*

**ЧӘКӘЛӘШ** *и.* Чәкәләшү эше, гамәле. *Чәкәләшнең азагы болай тәмамланды: Валентинаның гаризасы нигезендә, хулиганлыгы өчен, суд Михаил Ибраһимовны унбиш көнгә хөкем итте.* Н.Әхмәдиев. *«Үчти, үчти» диешә торгач башланган сугыш иде теге чәкәләш.* Ф.Баттал

**ЧӘКӘЛӘШҮ** *ф. сөйл.* 1) Кем беләндер кычкырышу, бәрелешү, бәхәсләшү; каршы чыгу. *Кайда да булса нервы бозып, чәкәләшеп, тәненә җиңеллек алырга яраткан Дилбәр ханым бүген тәмам ватылып, башы тубал булып өенә кайтып керде.* М.Галиев. *Әмма «Буби» мәдрәсәсен оештырып, Ишми ишан шикелле карагруһлар белән чәкәләшеп, патша чиновниклары белән судта бәрелешеп зур тәҗрибә туплаган, ихтыяр*

*көчен чыныктырган Габдулла Буби бирешми, аң-белемгә сусаган кешеләрне эзләп таба, аларны үз тирәсенә туплый һәм башлаган эшен дәвам итә.* Т.Әйди // Әйткәләшү, тиргәшү, талашу. *Суфияттәй белән Фирая чәкәләшеп бәрелешерләр кебек.* К.Кәримов

2) Кыйнашу, сугышу, бәргәләшү. *Шул вакытта алар кан дошманнар кебек чәкәләште.* В.Имамов. *Әллә ул армиягә ычкынды, әллә, шәһәрнекеләр белән чәкәләшеп, төрмәгә эләкте.* Н.Гыйматдинова

**Чәкәләшә башлау** Чәкәләшергә тотыну. *Синекеләр, минекеләр дип чәкәләшә башласаң, өйдән бәрәкәт кача.* Д.Каюмова

**Чәкәләшеп алу** Бераз, җиңелчә чәкәләшү. *Шулай да ул егет белән генә чәкәләшеп алмыйча булмады.* Р.Төхфәтуллин. *Картлар әнә шулай әйбәт кенә чәкәләшеп алдылар.* Г.Галиев

**Чәкәләшеп йөрү** Гел, һәрвакыт чәкәләшү. *Шулай да ул, үзенең элекке даны бетүгә килешә алмыйча, шактый гына вакыт Әндәлис белән астыртын бәрелешеп, чәкәләшеп йөрде.* Х.Сарьян

**Чәкәләшеп китү** Кинәт чәкәләшә башлау. *Элеграк шулай өчәүләшеп чәкәләшеп киткәндә, яшь бабай гел Габделхәйне яклый торган иде.* Н.Фәттах. *Энекәш төшереп алган да, иптәшләре белән аз гына чәкәләшеп киткәннәр.* З.Мурсиев

**Чәкәләшеп тору** Гел чәкәләшү; хәзер, әле чәкәләшү. *Сугышның соңгы биш аенда Мурзин партизаннарына власовчылар белән еш чәкәләшеп торырга туры килә.* Р.Зарипов. *Бала-чага гел чәкәләшеп тора бит инде.* Р.Зәйдулла

**ЧӘКӘН** I *и.* Кайбер үсемлекләрнең тыгыз булып утырма чәчәкләр урнашкан итчел үзәкле башаксыман чәчәк төркеме. *Днепропетровск шәһәренең Кукуруз институты, Идел буе районнарында чәкән өлгерерлек кукуруз үстерү өчен, салкынга чыдам сорт эзләп тапкан.* К.Кәримов. *Аның [камыш сабагы] очында кеп-кечкенә чәкән тырпаеп тора.* А.Хәлим

**ЧӘКӘН** II *и.* Җеп яки ука белән күпертеп чигелгән бизәк. *Нечкә бармаклар белән чигелгән матур чәкән төсле һавада асылынып тора!* Ш.Камал

**ЧӘКӘН** III *с. иск.* Матур, чибәр. *Сарайның иң чәкән бүлмәләренең берсендә менә шул Җамисап йоклап ята иде.* Ф.Халиди

**ЧӘКӘН** IV *и. диал.* Озын сапка утыртылган чүкечтән гыйбарәт борынгы корал. *Күсәк әзерләп, тимер чәкәнне билгеләрәк урынга урнаштырып куючылар да юк түгел иде.* М.Галәү

◊ **Чәкән шар сугу** Чирәм өстендә кәшәкә таяк белән шар сугып уйнау. *Көз көннәренең иң кызыклы уеннарыннан чәкән шар сугу бик күңелле була иде.* М. Гафури

**ЧӘКӘНБАШ** *и. сөйл. к.* **чәкән** I. *Әйтергә кирәк, бәйрәкәлеләр тәрбияләп үстергән кырлар патшасының биеклеге ике метрдан артык, бер сабакта өчәр-дүртәр чәкәнбаш җитешкән.* Ютазы таңы

**ЧӘКӘНЛӘ́Ү** *ф.* Чәкән (II) ясап чигү, чәкән белән бизәү. *Камзулны чәкәнләү*

**ЧӘКӘШТЕРҮ** *ф. сөйл. к.* **чәкештерү**. *Барлык ярәштерә, юклык чәкәштерә.* Әйтем. *Чәкәштерде бәллүр бокалларны – Хис шәрабын дөнья татыйсы!* Ф.Яхин

**ЧӘКӘШҮ** *ф. сөйл.* 1) *к.* **чәкешү**. *Шуны гына көткән кебек, мөлдерәмә шәраб тулы бокалны тотып, Визигаст король үзе Атилла янына килде һәм хан белән чәкәште.* М.Хәбибуллин

2) *к.* **чәкәләшү**. *Ләкин кайчандыр Гыйльметдин белән чәкәшкән чакта Андрей Петрович әйткән киңәшне истә тотып, үз-үзен дуамал чыгышлардан тыеп килә.* К.Нәҗми. *Андый вакыйгалар, чәкәшеп алулар баштарак еш булгалады.* М.Хәсәнов

**Чәкәшә башлау** Чәкәшергә тотыну. *Рифатның болай чистарынуы, күңеле сафлану галәмәте әлегәчә тәҗрибәсендә булмаганлыктан, бераз кыенгарак та килә, чөнки дөньялык галәмәтләренә каршы барып, яшәеш төшенчәләре белән күңел кичерешләре һәм хисләре үзара чәкәшә дә башладылар.* Ф.Яхин

**Чәкәшеп бетү** Тәмам чәкәшү

**Чәкәшеп тору** Даими, гел чәкәшү. *Әнә һәр көнне диярлек чәкәшеп торасыз.* М.Хәбибуллин

**ЧӘКЕЛДӘТҮ** *ф. сөйл.* 1) *төш. юн. к.* **чәкелдәү**. *Эшсезлектән тилмергән Ганс Нәбиев дигән егетебез аяк астындагы бер гөнаһсыз буш шешәне кулындагы чүкече белән чәкелдәтеп ватарга керешкән иде дә, һәрвакыт җитди Таня Лазарева, уклы сүзләрен кадап, аны шып туктатты.* Р.Вәлиев

2) *к.* **чәкештерү**. *Теге яктан кемнәрнеңдер чынаяк чокырын чәкелдәтеп җырлаулары, ярылганчы көлүләре ишетелә.* К.Нәҗми

3) *куч.* Ату, атып үтерү. *Җәйпәк борынлы казак тиз генә кобурасына тыгылды: «Этен чәкелдәтергә рөхсәт итегез, ваше благородие».* Г.Гобәй

**ЧӘКЕЛДӘҮ** *ф.* Пыяла, чынаяк, калай һ.б.ш. әйберләр җиңелчә бәрелгәндә чыңлап кую

**ЧӘКЕШТЕРҮ** *ф.* 1) Фикерләрнең, хисләрнең уртаклыгын белдерү йөзеннән рюмканы, стаканны һ.б.ш. башка берәүнең рюмкасы, стаканы һ.б.ш.на тидереп алу; чәкәшү. *Бәллүрләребезне сүзсез генә чәкештереп, шәрабны йотып җибәрдек.* А.Хәлим. *Чәркәләрне чәкештергән чакта, Шәраб түгел, шигырь түгелә.* Г.Морат

2) *күч.* Котыртып, кемнәрнедер берберсенә каршы кую; өстерү. *Чит-ят «мин» астыртын гына җаныңа оялый да, фикерләрең белән чәкештереп, уйниятләреңне үзгәртеп, шик-шөбһәләргә уратып ята.* Н.Гыйматдинова. *Кыскасы, чәкештермәскә кирәк иде ике бөек затны!* Р.Фәйзуллин

3) Кылыч, сөңге кебек коралларны бер-берсе белән чалыштыру. *Инде тагын ике галим тарих, фәлсәфә, әдәби тәнкыйть күгендә кылыч чәкештерә – фикер дөньясында ут, ялкын уйный.* М.Мәһдиев. *Чура морза, элекке гадәт буенча, хан капкасыннан чаптырып килгән уңайга гына узып китмәкче иде дә, тоткавыллар, сөңгеләрен чәкештереп, юлына аркылы төштеләр.* М.Әмирханов

**Чәкештерә башлау** Чәкештерергә тотыну. *Барысы да, аягүрә басып, бокалларын чәкештерә башлады.* В.Имамов

**Чәкештереп алу** Бераз чәкештерү. *Кан чәчрәп чыкканчы, чырайга чырай, маңгайга маңгай чыкы-чыкы чәкештереп алганнан соң, капчыкка әйләнгән гәүдәләрне ике якка селтәп ыргытты һәм куркудан өнсез калган кызларны, тыныч кына култыклап, машинага таба алып китте.* М.Галиев. *Болар янә бокалларын чәкештереп алганнан соң, Зурмөгезнең теле ачылганнан-ачыла гына бара икән.* Н.Сәйяр. *Алар, матур зеңгелдәү авазы чыгарып, шәрабларын чәкештереп алдылар.* Р.Мөхәммәдиев

**Чәкештереп кую** Бер тапкыр чәкештерү. *Меңбашы, теләр-теләмәс кенә, яңа туып килгән император белән чәкештереп куйды.* Р.Сәгъди

**ЧӘКЕШҮ** *ф.* 1) Кем беләндер савытларны чәкештерү; чәкәшү. *Шәнгәрәй, чынаягын тотып, Шәрәфи белән чәкешеп эчте.* Г.Ибраһимов. *Бер тынга аптырашта калган кунакларга Сабит*

*озак уйларга ирек бирмәде, ялт кына шешә ачып, коньякны киңчә төпле зур бокалларга мул итеп койды да чәкешергә үрелде.* А.Гыйләҗев

2) Бәрелешү, кемгә дә булса бәрелү. *Алар ишектән чыкканда чәкештеләр*

3) Ярашмау, туры килмәү, берберсенә капма-каршы булу. *Рифатның болай чистарынуы, күңеле сафлану галәмәте әлегәчә тәҗрибәсендә булмаганлыктан, бераз кыенгарак та килә, чөнки дөньялык галәмәтләренә каршы барып, яшәеш төшенчәләре белән күңел кичерешләре һәм хисләре үзара чәкешә дә башладылар.* Ф.Яхин

4) *күч.* Кем беләндер сүзгә килү, әйткәләшү, бәрелешү. *Төшеңдә курыксаң, бер кеше белән чәкәшерсең һәм гаугаланырсың, ди.* Ф.Яхин

**Чәкешә башлау** Чәкешергә тотыну

**Чәкешә язу** Чак чәкешми калу. *Мансур ишек катында кемнәр беләндер чәкешә язды.* М.Әмирханов. *Бер йортта яшәүче Наташа белән маңгайга маңгай чәкешә язгач та, шулай дип көлештек.* Шәһри Казан

**Чәкешеп алу** Аз гына чәкешү. *Борынгы вакытларда шушы рәвешле чәкешеп алу гадәти күренеш һәм кабул кылынган тәртипләрнең берсе генә булганлыктан, аңа аерым игътибар бирелмәскә дә мөмкин.* Ф.Яхин

**Чәкешеп тору** Даими яки әледәнәле чәкешү; хәзер, әле чәкешү. – *Чәкешеп торган чакларына барып кердем, бәйрәм итеп яталар, – дип борылып керде.* Сөембикә

**ЧӘКИ** *и. диал.* 1) Чирек литр сыешлы шешә; чүлли. *Бу хәлләрдә шефларның өмәгә килгән һәр җан башына берәр чәки сөт тияр!* Э.Касыймов

2) Чүрәкәй уенының бер төре (балалар уены)

**ЧӘКМӘРӘ** *рәв. к.* **чәлпәрәмә**

◊ **Чәкмәрә килү** Нәрсәнеңдер астыөскә килү, чуалчыклану, рәте китү, җимерелү. *Дөньясы чәкмәрә килде.* К.Тинчурин

**ЧӘКМӘШӘ** *и. диал.* Шар сугу уенында кулланыла торган таяк; кәшәкә. *И көләч йөзле малай, Чәкмәшәңне куй да бер якка, йөгер, кил каршыма! Шартаяктан да күңеллерәк бер әйбер бар синә.* Г.Тукай

**ЧӘКҮ** *ф. сөйл.* 1) Бәрү, сугу, ору. *Ну шуннан инде тимер белән чәкедем, йомдырдым мактанчыкны.* Н.Гыйматдинова

2) *күч.* Ату, атып үтерү. *Илалетдин карт винтовкасыннан бер бүрене нәкъ маңгаена чәкеде, аннары, аны корып тормастан, ау мылтыгын алып, икенчесен иләк итте.* З.Мурсиев

3) *күч.* Исерткеч эчемлек эчү, салу, кәгү. *Әллә камерада чәкеп алдыңмы?* И.Салахов

**Чәкеп алу** Бер тапкыр чәкү

**Чәкеп тору** Хәзерге вакытта чәкү. *Фираз оста снайпердай, Үз рогаткасы белән Атып, чәкеп кенә тора.* Ф.Яруллин

**ЧӘКҮШКӘ** *и. рус* 1) Күчәрнең очочларындагы тишеккә тәгәрмәч төшмәсен өчен кертеп куела торган чөй. *Арба тәгәрмәчләрендә дә агач чәкүшкә!* Н.Кәримова. *Күз ачып йомганчы теләсә кайсыбызны, чәкүшкә итеп, арба күчәренә тыга да куя.* Р.Газиз

2) 0,25 литрлы аракы шешәсе. *Җәмил куен кесәсеннән чәкүшкә белән стакан чыгарып куйды.* З.Мәхмүди

◊ **Чәкүшкә бәрелү** Сүзгә килерлек сәбәп чыгу. **Чәкүшкәләр бәрелешү** Сүзгә килү, үзара тиргәшү. *Ничектер мәҗлесебезнең рухы үзгәрде, чәкүшкәләр дә бәрелешеп алды.* А.Шамов. **Чәкүшкәләр эләгешү** *к.* **чәкүшкәләр бәрелешү**. **Чәкүшкәсе эләгү** *к.* **чәкүшкә бәрелү**. *Йомшак кына, сөйләр сүзен дә авызыннан көчкә чыгара торган бер малай иде, ә хәзер үзенә якын барып кара, чәкүшкәң эләкмәсен!* Г.Толымбай

**ЧӘКЧӘК** *и. фар.* Камырны эрбет чикләвеге зурлыгында яки хөрмә төше кебек озынча итеп кисеп, кайнап торган майда пешереп, барысын бергә баллап катырып ясалган ашамлык; кактөш. *Чәйгә бавырсак, чәкчәк бар.* Г.Ибраһимов. *Хәдичә танышу-туганлашу хөрмәтенә зур ук тәлинкәгә чәкчәк өеп катырган иде.* К.Тимбикова

**ЧӘК-ЧӘК** *рәв. диал. к.* **чак-чак**. *Әнкәй пешерде чәкчәк, Капкалыйм аны чәк-чәк.* Н.Әхмәдиев

**ЧӘКЧӘ́К АШЫ** *и. этн.* Кияү кыз катына кереп кайткач, үзенең дусишләрен, якыннарын җыеп үткәрелә, иң ахырда табынга чәкчәк китерелә торган мәҗлес. *Кияү кәләшкә бер килеп киткәннән соң, кыз ягы чәкчәк ашы үткәрә.* Казан утлары

**ЧӘЛДЕРҮ** *ф.* 1) *гади с.* Урлау. *Чәлдереп бер елны, Кылый гүя урманга шылган.* Х.Бәдигый. *Чебеш я үрдәк бәпкәсе чәлдерсә дә, шунда кереп кача иде ул.* А.Хәсәнов

2) *сөйл.* Әйтмичә генә, бик тиз кая да булса китү; элдертү, таю. *Шулай [становой] туры волость идарәсенә чәлдергән.* Х.Кәрим

**Чәлдерә башлау** Чәлдерергә тотыну. *Минем белән талаша-талаша, колагын усал шомартып, улакның бер башыннан башакны чәлдерә башлый.* А.Хәсәнов

**Чәлдереп йөрү** Һәрвакыт чәлдерү

**Чәлдереп тору** Гел, һәрвакыт чәлдерү

**ЧӘЛПӘК** *и.* **1.** Камырдан ясалган вак-вак җәймәләрне кайнап торган майда пешереп әзерләнгән ашамлык; кош теле. *Чәй эчәргә өстәлгә чәлпәк китерәләр.* Сөембикә

**2.** *с. мәгъ. диал.* Җәенке, җәлпәк. – *Менә бу егетне цехка эшкә алырбыз, – диде, каршы әйтмәслек фәрман тоны белән, яссы, чәлпәк битле, әмма бик заманча киенгән, озын буйлы, күтәренке чәчле хатынга.* Т.Галиуллин

**ЧӘЛТЕР** *и. диал.* Балтыр, сыйрак. *Эт, каһәр төшкере, яңа алынганлыгы, актык акчама алынганлыгы белән һич исәпләшеп тормастан, минем әлеге биек үкчәле драп галошларымның берсен биш-алты төймәсе белән берьюлы умырып алган, һәм кереп утыргач сиздем: чәлтер сөягемә хәтле үткәзеп аягымны да умырган – үкчәмә таба җылы кан ага иде.* Ф.Хөсни

**ЧӘЛҮ** *ф. гади с.* Урлау, чәлдерү. *[Садрый:] Кара син аны, ә! Бер тәңкәлекне чәлде бит!* Г.Камал. *Төнне көтә угрылар, Бер-бер нәрсә чәлү өчен.* Ә.Низамова // Кулга төшерү, үзләштерү; алдау юлы белән табыш алу. *Һәм дә Мәскәүдән дә маллар алмышым. Сумына туксан тиенне чәлмешем.* Г.Тукай

**ЧӘМ** *и.* 1) Борынгы төрки мәҗүсилектә, хәзерге буддизм динендә махсус киемнәр киеп үтәлә торган тантаналы келәү, мистерия

2) Азарт, зур теләк, дәрт; мавыгу, һәвәслек. *Аларның инде түзерлек тәкатьләре калмаган иде, һәркайсы чәм белән яна.* З.Мурсиев. *Ахыргача өметләре сүнмәгән, малайларча чәм белән эшләгән абыйларның да йөзләре сүрелде.* Д.Булатова

**ЧӘМӘЙ** *и. диал.* 1) Хайваннарның тоягы өстендәге буын сөяге, ашык. *Сарык чәмәе*

2) Уен өчен кулланыла торган шул сөяк; кузна. *Чәмәй сугып йөргән балачага да шунда.* Кызыл таң

**ЧӘМӘН** *с. диал. к.* **чаман**. *Чабышкы – узыш аты, юрга һәм юртак – чабу рәвешләре буенча бирелгән атамалар, чаман (чәмән) – әкрен йөрешле ат, чалык – тиз йөрешле ат, чарыс – тиз йөрешле ярсу ат, җилаяк ат – чалык ат, артак – кыргыйлашкан,*

*өйрәтелмәгән яисә холкы бозык ат, тухшун – көтмәгәндә тибә торган холыксыз ат.* А.Тимергалин

**ЧӘМЛЕ** *с.* Нәрсәне дә булса чәм, көчле дәрт белән, мавыгып һәм бирелеп эшләүче, азартлы. *Чәмле кешенең күп сөйләргә, көйсезләнергә чамасы юк.* А.Хәлим

**ЧӘМЧӘ** *и.* **1.** 1) Чигелгән бизәк, чигеш. *Матур чәмчә*

2) Күнгә кисеп каела торган бизәк. *Чүәк чәмчәсе*

**2.** *с. мәгъ.* Чигеп, каеп эшләнгән. *Читек кунычымда – чәмчә бизәк, Бала итәк тоткан күлмәгем.* С.Әхмәтҗанова

**ЧӘМЧӘЛЕ** *с.* Чәмчә каелган, чәмчә белән бизәлгән. *Гайникамал апасының әйтүләренә караганда, элегрәк бу өйдә хәситә, тәңкәле изү, казакин, җилән, чәмчәле читек, укалы итәк, төсле сафьян читекләргә тикле теккәннәр, имештер.* М.Хәсәнов. *Аягыңда чәмчәле кунычлы болгар итеге.* А.Гыйләҗев

**ЧӘНӘШКӘ** *и. диал.* Таудан шуу яки кечерәк йөк ташу өчен кечкенә чана. *Яңа ел вечерына дип, чәнәшкә белән утын алып кайткан идек, вечерның да рәте булмады...* А.Гыйләҗев

**ЧӘНЕЧКӘК** *с.* **1.** Чәнечкеле, чәнчә торган. *Чәнечкәк сабаклы куак*

**2.** *и. мәгъ.* Чәнечке, тикән. *Кулга чәнечкәк кадалды*

**ЧӘНЕЧКЕ** *и.* **1.** 1) Кайбер үсемлекләрдә һәм хайваннарның тиресендә була торган энә, очлы, нечкә һәм каты үсенте; тикән. *«Рәхмәт», – дип пышылдады, Сөембикәнең күкрәгенә роза чәчәгенең чәнечкесе кадалды.* Ф.Садриев. *Гиппопотам да искитәрлек чибәрләрдән түгел, ә дикобраз кешене үзенең чәнечкеләре белән үк куркытып тора...* К.Гыйззәтов

2) Кисәкле ризыкларны чәнчеп алу өчен, сабының бер очы берничә япьле итеп ясалган әсбап. *Кунаклар шау-гөр килеп алдылар, пычак, чәнечке тавышлары ишетелде.* Г.Әпсәләмов. *Әти чәнечке-кашыкларны аерым бер ваклык белән тезеп чыккан.* А.Гыйләҗев

3) Хәрби эштә киртә ясау һ.б.ш. максатлар өчен кулланыла торган тимерчыбыкның кагылганда чәнчә торган чыгынтысы. *Фәритнең кулын тимерчыбык чәнечкесе тырнап узды.* Р.Низамиев

**2.** *с. мәгъ.* 1) Чәнчә торган чыгынтылары булган, энәле. *Чәнечке чыбык, һич булмый чыгып, Гитлер этләре канны эчә сыгып.* Бәет

2) *күч.* Зәһәр, төртмәле. *Кызлар да бит Үртәп китә: Чәнечке сүз Төртеп китә.* Ш.Галиев

◊ **Чәнечке җибәрү** Зәһәр сүзләр әйтү, ачы теллеләнү, төртмәле сүз әйтү. *[Байсаров:] Ярулла абзый, сез миңа урынсыз чәнечке җибәрәсез.* Ф.Бурнаш

**ЧӘНЕЧКЕЛӘ́Ү** *ф.* 1) Төрле җирдән чәнчү, чәнечке куллану. *Апа ризыкны чәнечкеләде*

2) *күч.* Төрттереп, күңелгә тия торган сүзләр куллану. *Син алай чәнечкеләп сөйләшмә инде.* З.Хәким. *Мәзәк итеп, бер урында сүзләрен чигүләп-матурлап, икенче урында майлап-баллап, өченче урында чәнечкеләп-кылчыклап сөйләде.* С.Поварисов

**ЧӘНЕЧКЕЛЕ** *с.* 1) Чәнечкесе, энәсе булган (кайбер үсемлекләр һәм хайваннар тур.). *Матур гөл чәнечкеле була.* Әйтем. *Тәрәзә төпләре, өстәл-урындыклар, киштә-шүрлекләр, идәннең дүрт почмагы чәнечкеле кактуслар белән тулган.* Г.Гомәр. *Саргылт яшел тау итәкләрендә, кыялар һәм чәнечкеле күгән куаклары арасында кәҗә көтүләре йөри.* Р.Мостафин

2) Чәнчә торган, чәнчүчән. *Ләкин озын тырнаклы бер карт аның күз кабакларын ачып, ниндидер чәнечкеле агач ботагы белән терәтеп куйды.* Ф.Яруллин

3) Кагылганда чәнчә торган чыгынтысы булган (тимерчыбык һ.б.ш. тур.). *Каршында чәнечкеле тимерчыбык киртә пәйда булгач, ул капыл туктарга мәҗбүр булды.* А.Тимергалин. *Бөтен ягыннан да чәнечкеле биек коймалар белән уратып алынган.* В.Имамов

4) *күч.* Шома гына бармаган, читен. *Чәнечкеле тормыш баскычлары*

5) *күч.* Зәһәр, усал, яман, күңелгә тия торган. *Әбүбәкер останың чәнечкеле сүзләрен Корнай батыр да эләктереп алды.* В.Имамов. *Ник дигәндә, соңгы вакытта Исмәгыйль үзен дорфа тота, чәнечкеле сүзләр очырта.* М.Әмирханов

**ЧӘНЕЧКЕЛЕ́ БАЛЫК** *и. зоол.* Чәнечкеле балыклар семьялыгыннан аркасында һәм корсагында йөзгечләр урынына чәнечкеләр булган сөякле вак балык; *русчасы:* **колюшка**

**ЧӘНЕЧКЕЛЕ́ БАЛЫКЛАР** *и. зоол.* Чәнечкеле балыксыманнар отрядыннан, өч чәнечкеле балык, тугыз чәнечкеле балык һ.б.ларны берләштерә торган семьялык; *русчасы*: **колюшковые**

**ЧӘНЕЧКЕЧ** *и. диал. к.* **чәнечке** (*1 мәгъ.*)

**ЧӘНТИ́ БАРМАК** *и. к.* **чәнчә бармак**. *Галиулла Мәскәү госпиталендә чәнти бармагын кистергәннән соң Эстәрлетамакка килеп җиткәч, айдан артык госпитальдә ятты.* З.Зәйнуллин. *Маэмай малайның чәнти бармагын тешләп тә алды.* А.Гыймадиев

**ЧӘНЧӘ БАРМАК** *и.* Атсыз бармактан соң килгән иң нечкә һәм иң кечкенә бишенче бармак. *Чәнчә бармагында зур бриллиант кашлы йөзек ялтырый.* М.Галәү. *Чирәм арасында чәнчә бармак башы хәтле генә көл өемнәре бар иде.* А.Тимергалин

**ЧӘНЧЕ́ЛГӘНЧЕ** *рәв.* 1) Егылганчы. *Минем геройларым кабакларда чәнчелгәнче сыра эчәләр.* Һ.Такташ

2) Үлгәнче. *Сугышта чәнчелгәнче көрәшергә әзер*

3) Беткәнче, юкка чыкканчы. *Машинасы чәнчелгәнче куды*

**ЧӘНЧЕЛДЕРҮ** *ф. сөйл.* 1) Җиңү, егу. *Сокланып, исләре китеп, алар каш астыннан гына атаклы Тотышны – орышта ханның ике алыбын чәнчелдергән яшь батырны күзәттеләр.* Н.Фәттах

2) Үтерү, дөмектерү. *Чебен үтерергә дә кызганган яшь кыз бүген ике немецны чәнчелдерде.* С.Поварисов

3) Бетерү, юкка чыгару. *Англиядә худка киткән пар машинасы феодализмны чәнчелдерде.* А.Гыйләҗев

**Чәнчелдереп ату** Кинәт, тиз арада чәнчелдерү. *Ибраһим урынына менгән Илһам ханны Мөхәммәтәмин Мәскәү көче белән чәнчелдереп атты.* В.Имамов

**ЧӘНЧЕЛҮ** *ф.* 1) Нинди дә булса очлы нәрсә тишеп керү, эчкә керү; кадалу. *Кулына курпылар чәнчелде, битенә тир бәреп чыкты.* Ә.Гаффар. *Бу нурлардан Җәүдәтнең күзләренә гүяки меңләгән кайнар энәләр чәнчелде, шулкадәр озак йоклаганына үзеннән-үзе оялып куйды.* А.Хәлим

2) *күч. сөйл.* Бик каты егылу, егылып төшү; мәтәлеп барып төшү. *Артык югарыга ымсынып сыек ботакка кунакласаң, чәнчелеп төшкәнеңне көт тә тор.* А.Хәлим

3) *күч.* Бәрелү. *Алда барган икенче бер машинаның артына барып та чәнчелде.* Р.Кәрами

4) *күч. гади с.* Үлү, дөмегү. *– Казакъ йортының өстендәге бер яман адәм чәнчелде, инде ил үз хәлен үзе белер, казакъ йорты найман балаларына яңадан кол булмас, – дип, үлгән Байтүрә урынына энесе Якупның утыру ихтима-*

*лына каршы, үз кешеләре арасында, җыелып-җыелып, утлы сүз йөртүдә дәвам кылдылар.* Г.Ибраһимов

5) Бетү, юкка чыгу, таркалу, тузу. *Бу вакытта күзәтүче командирларның шатлыгы кырга сыймый: әһә, дөмекте, чәнчелде, дип уйлыйлар.* С.Поварисов. *Бер килеп чәнчелә әле ул андый кеше.* Н.Фәттах

6) **чәнчелгере, чәнселсен** Каргау, нәфрәт яки битарафлык белдерү сүзе. *Әллә өйдә калган, чәнчелгере.* А.Алиш. *– Яңгыры да, чәнчелгере, туктый белмәде, – диде, тирә-ягына каранып.* Р.Кәрами. *Чәнчелсен сазлыгы, у-у, ничек безелдиләр!* А.Гыйләҗев. *Чәнчелсен кәбестәләре!* Н.Гыйматдинова

7) Юньсез, начар, яман. *[Карчык:] Һаман җитмәгән икән әле чәнчелгән хатынга, җитмәгән икән әле!* Г.Гобәй. *[Гаптерәхим:] Чәнчелгән нәрсә, башак бирсәң – башакны чөеп ташлый, печән бирсәң, ашамый.* Т.Гыйззәт

◊ **Чәнчелеп беткән** *к.* **чәнчелгән**. *[Гафифә:] Чәнчелеп беткән җөйче, шулкадәр әйттем: «Факиһәнеке төсле матур булсын, яхшы итеп тек», – дип.* Г.Камал

**ЧӘНЧЕМ** *и.* Җөйнең энә белән бер чәнчеп тегелгән арасы; атлам. *Тамбурлы чәнчем – тукыма аша чөпчеп алынган күз ул.* Сөембикә

**ЧӘНЧЕП** *рәв.* Мәсхәрәне, көлүне белдереп; мәсхәрәле рәвештә. *Чәнчеп әйтү. Чәнчеп сөйләшү*

**ЧӘНЧЕШ** *и.* Чәнчү хәрәкәте; чәнчү рәвеше. *Китә орыш, суеш, чәнчеш.* М.Хәбибуллин. *Китте чәнчеш, китте приклад белән сугулар, китте атыш.* З.Зәйнуллин

**ЧӘНЧЕШҮ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **чәнчү**. *Атышалар, чәнчешәләр, бугаздан буалар – мәетләрне таудай өя торган сугышлар бара.* А.Гыйләҗев. *Бу вакытта дүрт мушкетёр белән тагын Франциядән Англиягә, инглизләрдән французларга «ат чаптыра», кардиналның шпионнары белән чәнчешә, мадам Бонасьега үлеп гашыйк идем.* Ф.Яхин

2) Тәндә кискен, чәнчүгә охшаш авырту барлыкка килү. *Малайлар кое янында безнең озак маташуны мәзәк иттеләр, өрәңге тубырыннан ясаган шараны юри безнең яккарак тәгәрәтәләр, ачуым килеп, шараны тибеп җибәрим дигән идем – тезем чәнчешә, ыңгырашуымны сизми дә калдым.* А.Гыйләҗев. *Харис кулы әрнеп чәнчешүдән кычкырып җибәрде.* З.Мурсиев

**Чәнчешә башлау** Чәнчешергә тотыну. *Минем тәнем өзгәләнә, ачыргалана, чәнчешә башлый.* А.Хәлим. *Кинәт кенә күз чәнчешә башлады.* М.Маликова

**Чәнчешеп алу** Бераз гына чәнчешү. *Яңгырбай белән Арысланбай ярым көлкеле, ләкин агулы сүз белән чәнчешеп тә алдылар.* Г.Ибраһимов

**Чәнчешеп кую** Кинәт кенә яки бер тапкыр чәнчешү. *Заһидулла хәзрәтнең йөрәге чәнчешеп куйды: нинди генә хәйләләр кормады ул, нинди генә хыянәтләр эшләмәде, ә нәтиҗәдә ни килеп чыкты.* Г.Мөхәммәдова

**ЧӘНЧҮ** *ф.* 1) Салкын коралның очлы башын кемнең дә булса тәненә кадап кертү, батыру. *Янә иң кече сеңелебез госпитальдә эшли иде, мәҗрух немец пычак белән кулына чәнечкән...* Ә.Еники. *Алар һаман аны каргаган, аңа таш аткан, сәнәкләр, сөңгеләр белән чәнчергә ябырылган.* Г.Гыйльманов

2) Берәр очлы нәрсәне кая да булса кадау, кадап кую. *Һич кенә дә авыл тормышына охшамаган кырыс тәртибе, ефрейтор, сержантларның җилкәсенә әллә ничә йолдыз чәнечкән офицерлардан да хәтәр кыланып, борынны илләм чөеп йөрүләре, сүтелә-җыела торган автоматлары, тимер кашык, кружкалары – һәммәсе аның өчен үзгә бер яшәеш иде.* Т.Галиуллин

3) Чәнечке яки берәр үткен очлы нәрсә тәнгә тиеп авырттыру, тәндә авырту барлыкка китерү. *Билчәннәр кулны да чәнчә.* Г.Ибраһимов

4) *күч.* Кемгә дә булса чәнчүле, зәһәр сүзләр әйтү, төрттерү. *Ярым шаярган, ярым чәнечкән тавыш белән нәтиҗәләде.* Г.Ибраһимов

5) Авыр сүзләр кемгә дә булса начар тәэсир итү, күңеленә тию; кадау. *Аның чем-кара күзләре факел яктысында артыграк ялтырый, көлемсерәп каравы да «князьләргә» яхшы тәэсир бирмичә, чәнечкән кебек тоелды.* Ш.Камал

6) Тәндә чәнчүле авырту барлыкка китерү. *Йөрәк чәнчә*

7) Берәр нәрсә теккәндә энә ярдәмендә җепне тукымага үткәрү. *[Зөбәйдә] Менә баласына күлмәк тегә, Чәнчеп-чәнчеп ала инәсен.* Һ.Такташ

8) *сөйл.* Югарыга, өскә күтәрү. *Көтү тузгыган: сыерлар мөгриләр, атлар кешниләр, барысы да койрыкларын чәнчеп чабып йөриләр.* А.Алиш. *Хайваннар ниндидер куркыныч сизеп йөгерештеләр, ә этләр койрыкларын чәнчеп уладылар.* А.Нәҗми

9) Тезләрне бөгебрәк, өскә каратыбрак утыру. *Иван Илларионович та аңа, бүтән врачлар кебек үк, күтәрелеп карамады, җилкәсенә авыр йөк салган йөкче кебек иелеп нидер мыгырдады, берсен берсенә чәнчегән тезләрен атындырып куйды.* А.Гыйләҗев

**Чәнчә башлау** Чәнчергә тотыну. *Күңел – әүлия, диләр бит, дөрес сүз икән: Сабан туеннан кайтып та җиттем, түшәккә дә егылдым – эчем бора, сул кабыргам астында нәрсәдер тырный, чәнчә башлый.* Г.Ибраһимов. *Болай йомарлангач эч, күкрәк бик нык өшеми кебек, ә менә арка тагын да ныграк туңа, салкын үпкәләрне чәнчә башлый.* З.Мурсиев

**Чәнчеп алу** Искәрмәстән бер тапкыр чәнчү. *Ә менә хатын мәсьәләсенә кагылгач, йөрәгемне нидер чәнчеп алды.* В.Нуруллин. *Йөрәкне нидер чәнчеп алды.* А.Хәлим

**Чәнчеп бетерү** Тәмам тишкәләнгәнче чәнчү. *Әйе, аны госпитальгә китереп ташлаганнар иде, шунда бик нык газапладылар: бот төбен, аркасын озын энәләр белән чәнчеп-чәнчеп бетерделәр...* Х.Камалов

**Чәнчеп карау** Сынап, белү максаты белән чәнчү. *Харисның болай җиңелчә сөйләшүе Халидәгә ошамады, сынын турайтып, чәнчеп-чәнчеп карады.* М.Маликова

**Чәнчеп кую** Нәрсәне дә булса чәнчегән хәлдә калдыру; кинәт яки бер тапкыр чәнчү. *Мәкаләнең исемен күрү белән, Таңсылу ханым кинәт йөрәге чәнчеп куйганын тойды, аннары бит алмалары кызыша башлады, күз аллары караңгыланып китте.* А.Тимергалин. *Дамирның уены-чыны бергә, мине тешләргә тырыша, сүзләре белән чәнчеп-чәнчеп куя, мәгәр мин тыныч.* А.Гыйләҗев

**Чәнчеп тору** Туктаусыз чәнчү; хәзер, әле чәнчү. *Ә нәтиҗәләре йөрәккә уелып кала да гомер буе җанны әрнетеп, чәнчеп тора.* В.Нуруллин

**ЧӘНЧҮЛЕ** *с.* **1.** 1) Чәнчеп, кадап куелган; өскә каратып күтәртелгән

2) Чәнчеп-чәнчеп куя торган, чәнчеп алган кебек сизелгән. *Йөрәк турысында чәнчүле бер хәлсезлек тойган хәлдә, пышылдап диярлек әйтте.* Н.Фәттах

3) Мәсхәрәләп көлүне белдергән, зәһәр, мәсхәрәле. *Үтерелгән Фәхринең кайнесе комсомолец Шәяхмәт тә шөбһә белән Җиһанша картка карый һәм чәнчүле сүзләр әйтә.* Г.Ибраһимов

**2.** *рәв. мәгъ.* Кешедән көлеп, мәсхәрәләп, мыскыл итеп. *Гөләндәм чәнчүле итеп елмайды.* Б.Камалов

**ЧӘНЧҮ́ ҮЛӘНЕ** *и. бот.* Чатырчәчәклеләр семьялыгыннан зәңгәрсу яшел яфраклы күпьеллык чүп үлән; *русчасы:* **синеголовник**

**ЧӘНЧҮЧӘН** *с.* Чәнчә торган, чәнечкеле. *Тимерчыбыктан ясалган өчен чәнчүчән*

**ЧӘНЧҮЧӘНЛЕК** *и.* Чәнчүчән булу сыйфаты

**ЧӘҢГЕЛДӘ́Ү** *ф.* 1) Нечкә тавыш белән өрү (эт тур.). *– Аларның әнчек этләре дә бар әле. Чәңгелдәп каршыга чыгачак, – дип куйды Нияз.* С.Зыялы

2) *куч. сөйл.* Нечкә тавыш белән, гадәттә, кызу-кызу сөйләү (балалар яки хатын-кыз тур.). *– Юк, ул моряк була, мин – врач, – дип, чәңгелдәп сүзгә кушылды Сәвия, үзе әтисенең чал керә башлаган бөдрә чәчләрен бутап алды.* Х.Хәйруллин

3) *куч. гади с.* Гадәттә кискен нечкә тавыш белән тиргәү, орышу // Каршы әйтү, телләшү, ризасызлык белдерү

**Чәңгелдәп йөрү** Гел чәңгелдәү. *Бозау кадәрле эт артыннан бияләй кадәрле көчек чәңгелдәп йөргән кебек.* Р.Закиров

**Чәңгелдәп тору** Гел чәңгелдәү; хәзерге моментта чәңгелдәү

**Чәңгелдәп яту** *сөйл. к.* **чәңгелдәп тору**. *Анда каравылчыны шаккатыргыч яңалык көтеп торган: кечкенә этен, каравыл өенә кертеп, мичкә ябып куйганнар, мескен көчек шуннан чәңгелдәп ята.* З.Хөснияр

**Чәңгелди башлау** Чәңгелдәргә тотыну. *Инде җанын җәһәннәмгә җибәрдем дип кенә торганда, тагын икәү-өчәве чәңгелди башлады, кулны караңгыда бутый-бутый, алар белән сугышырга керештем.* Ш.Маннур

**ЧӘҢГЕЛДЕК** *с.* **1**. 1) Нечкә тавыш белән өрә торган. *Минем этем кечкенә, әмма бик чәңгелдек, усал, Сигнал кушаматлы булыр.* З.Хөснияр. *Эт димәсәң, хәтере калыр, бияләй хәтле генә чәңгелдек бер нәрсә инде шунда.* И.Хәйруллин

2) *куч.* Нечкә (тавыш тур.). *Чәңгелдек тавыш*

**2.** *и. мәгъ.* 1) Гел өреп тора торган кечкенә эт. *Бер чәңгелдек өрә дә өрә*

2) Нечкә тавыш белән гел кычкырып сөйләүче хатын. *[Фатыйх:] Күземнән югал, чәңгелдек!* Р.Сәгъди

**ЧӘП** *иярт.* 1) Ашаганда, үпкәндә чыккан тавышларны белдерә

2) Яңакка, учка, су өстенә һ.б.ш.га ялан уч белән сукканда чыккан тавышны белдерә. *Чәп тагын берне, җаныкаем!* Г.Гомәр

**ЧӘПӘК** *и. диал.* 1) Кул учы белән сугу хәрәкәте; яңаклау. *Чыраена чәпәк алу*

2) *к.* **чәбәк**

3) *к.* **бәләк**

**ЧӘПӘЛӘК** *и.* Җиңелчә сугып алу. *[Хәзрәт:] Малайга чәпәләк бирәсеңме? Ныграк! Ныграк! Талны, мәсәлән, чыбык вакытында бөгеп калырга кирәк.* Ф.Әмирхан. *Ул гомерендә атасыннан кыен күрмәде. Анасы гына кайбер вакыт чәпәләк биргәли иде.* Г.Рәхим

**ЧӘПӘЛӘНҮ** *ф. сөйл. к.* **чәбәләнү**. *Язын каенны китереп утыртканда казыкка бәйләп куйганнар иде, хәзер бавы череп өзелгән, җил иркендә калган яшь агач үз сынын үзе тота алмыйча интегә бичара, чәпәләнә, әрнеп сызгыра.* А.Гыйләҗев. *«Сугымлык малыгыз юкмы?» – дип сорауга, ул: «Кая инде кешегә сатарлык терлек асрау, үзеңнең читтәге бала-чагаңны тәэмин итсәң дә бик шат буласың», – дип, нигәдер чәпәләнгәндәй җавап бирде.* Ватаным Татарстан

**ЧӘПӘЛӘ́Ү** ф. 1) Бәләк белән бәргәләү; гомумән берәр яссы нәрсә белән суккалау

2) Җиңелчә каккалау, суккалау; чәбәкләү

**ЧӘПӘЛӘШҮ** *ф. диал.* 1*) урт. юн. к.* **чәпәләү**. *Керне чәпәләшү*

2) *куч.* Сугышу, кыйнашу. *Оренбургтагы Вәли мулланың кадим мәдрәсәсендә сүз көрәштерү күп очракта якалашуга, мендәр белән чәпәләшүгә кадәр барып җитә иде.* С.Поварисов. *Яшьрәк чакта, дөньяларын онытып, канга батып чәпәләшеп яткан ике ир-атны берничә мәртәбә сугышудан туктаткан кешемен.* Ф.Тарханова

3) Тиргәшү, ызгышу

**ЧӘПӘМӘ** *и. диал. к.* **бәләк**

**ЧӘПӘ́Ү** *ф. сөйл.* 1) Камыр шикелле массаны берәр каты нәрсәгә көч белән китереп бәрү; бәреп сылау. *Яков Фёдорович балчык измәсен алып кирпечкә чәпи.* Ш.Бикчурин. *Илфар, бүселеп чыккан изманә алып, кирпечләр өеменә, җәй турысына чәпәде.* Б.Камалов

2) *диал.* Бәләкләү; чәпәләү. *Кер чәпәү*

3) Кирәкмәгән, килешмәгән берәр нәрсәне яки аннан-моннан, тиз-тиз, җыйнаксыз, ямьсез итеп ябыштыру, билге салу һ.б.ш. *Фотография дә чәпәгәннәр әле стенгазеталарына*

4) *куч.* Баш түбәсенә берәр ямьсез нәрсә кию яки тиз генә, аннан-моннан киеп кую. *«Бу ни соң бу?» – дияргә өлгермәде егет, Давыл аның баш түбәсенә чәчәкле түбәтәй чәпәде.* Н.Гыйматдинова. *Миргаяз кара костюм, ак нейлон күлмәк янына көрән төстәге капрон галстук та элеп куйды, зәңгәрсу шарф урап, яшел төстәге көзге пальтосын киде, башына бүреген чәпәде.* Р.Кәрами

5) *куч.* Кизәнеп сугу. *Бу китереп чәпәде сул кулы белән минем яңакка – бөгелдем дә төштем.* З.Зәйнуллин. *Шушы мизгелдән файдаланып, Заһит аңа тагын берне чәпәде.* Ф.Яруллин

6) *гади с.* Кинәтлек, көтелмәгән рәвештә күңелсез, начар берәр нәрсә бирү, кую. *Чәпәде укытучы двойка!* И.Юзеев. *Химиянең китабы да, дәфтәре дә килмәгән икән. Тагын «икеле» чәпиләр дигән сүз...* А.Әхмәтгалиева. *Чик сакчылары да, дусларча исәнләшеп, паспортларыбызга янә бер мөһер генә чәпәде.* Т.Әйди

7) Утлы коралдан ату. *Исмәгыйль «Лёнька трактор»ны өч көн сагалады һәм аңа дүртенче көнне, «Чулпан» ресторанында әшнәләре белән күңел ачып утырган җирендә, «Вальтер»дан чәпәде.* З. Мәхмүди

**Чәпәп алу** Җиңелчә чәпәү. *Алар көлешкән арада, Җәбир исен-акылын җыеп аягына ныклап басты да көтүченең яңагына берне чәпәп алды.* Н.Фәттах. *– Их син, юньсез сыер! – дип, Билгеш кызның арт санына чәпәп алды.* З.Мурсиев

**Чәпәп җибәрү** Көтмәгәндә, кинәт чәпәү. *Теге вакытта сабантуйда унлап сугыш чукмарын чәпәп-чәпәп җибәргәнен искә алганда, бу пәһлеванны сузып салыр өчен, кимендә егерме адәми зат кирәк булгандыр.* С.Поварисов

**Чәпәп кую** Бер тапкыр чәчпәү. *Баш түбәсенә чәпәп куйган мөселманча кара түбәтәй аңа килешеп тора һәм, кырыслыгын җуеп, мөлаемлык, сөйкемлелек өстәгән иде.* А.Гыйләҗев. *Әби-бабайлар да сайланып-сатулашып тормаганнар, авыл советы да, тиешле имзаларны җәһәт кенә җыеп, пичәтне чәпәп куйган.* Д.Гыйсметдин

**Чәпәп чыгу** Барысына да чәпәү. *Миллилек дип, орнаментлар, бизәкләр чәпәп чыгу белән генә әллә ниләргә ирешеп булмас шикелле.* Р.Вәлиев

**Чәпи башлау** Чәпәргә тотыну. *Казакъстанның юл полициясе безне туктатып, юк-бар өчен дә штраф чәпи башлады.* Р.Гыйлемханов. *Бу капкорсаклар башта үзләрен дәрәҗәләре белән*

*масайган түрәләр сыман тоттылар. Ә менә аркаларына хурлык тамгасы чәпи башлагач, сыгылып төштеләр, йөзләреннән кан качты.* С.Кальметов

**Чәпи тору** Һаман чәпәү. *Болар, теген, «made in Italy» дип, бирка чәпи тора, ә безнекеләр шуны өч бәягә аткара тора.* Н.Гыйматдинова

**Чәпи язу** Чак чәпеми калу. *Математикадан үзенә «икеле» чәпи яздылар бит бүген.* Т.Гарипова

**ЧӘПЕЛДӘТҮ** *ф. диал. к.* **чапылдату**. *Илсөяр, чыннан да ашагандагы шикелле итеп, авызын чәпелдәтеп куйды.* Г.Гобәй. *Хүррәм гаҗәпләнүдән кулларын чәпелдәтте.* В.Имамов

**ЧӘПЕЛДӘ́Ү** *ф. сөйл. к.* **чапылдау**. *Әнә үзең дә бер дә отказ бирмисең, авызың чәпелдәп кенә тора.* Г.Каюмов

**Чәпелдәп кую** Кинәт чәпелдәү

**Чәпелдәп тору** Гел чәпелдәү, хәзер чәпелдәү. *Ул кулындагы кәртләрен берберартлы шундый куәт белән өстәлгә китереп бәрә, чәпелдәп төшүенә карагандa, әйтерсең аның кулында катырғы кәгазь түгел, ә түбә калае иде.* Ф.Абдуллин. *Шул вакыт ярты чиләкне тутырып яткан кәрәкә балыгы, чәпелдәп, үзенең барлыгын белдереп куйды.* Г.Гыйльманов

**Чәпелди башлау** Чәпелдәргә тотыну

**ЧӘПЕЛДЕК** *и.* **1.** Өйдә кия торган артсыз аяк киеме; *русчасы:* **шлёпанцы**. *Эйлаттан узып барышлый гадәти «чәпелдек» сатып алдым, калган юлымны да шуның белән уздым.* Сөембикә

**2.** *с. мәгъ.* Артсыз, йөгәндә аякның очында гына тора торган. *Ул ачу белән урындыгыннан сикереп торды да, кырынмаган килеш, трикодан һәм чәпелдек чүәкләрдән урамга чыгып китте.* Ф.Садриев

**ЧӘПЕ́Л-ЧӘПЕЛ** *иярт.* Авызны җиңелчә чапылдатып ашаганда чыккан тавышны һәм шулай ашау рәвешен белдерә. *Чәпел-чәпел ашау*

**ЧӘПЕ́Л-ЧӨПЕЛ** *иярт.* к. **чәпел-чәпел**. *Чәпел-чөпел ипи кимерү*

**ЧӘПЕРЧЕК** *и. зоол.* Чәперчек кошлар семьялыгыннан һәрвакыт селкенеп торган озын тар койрыклы кечерәк кенә кош; сиртмәкойрык; *русчасы:* **трясогузка**. *Безнең өй кыегында чәперчек дигән кош бала чыгарган, шифер астында.* Ф.Яруллин. *Чәперчек берчак Ашаган борчак.* З.Мурсиев

**ЧӘП ИТҮ** *ф.* Сугу, чап итеп сугу. *– Риза, – дип, малай Солтанъяр бабасының киң учына чәп итеп сугып алды.* З.Мурсиев

◊ **Чәп итәргә дә җитмәү** Нәрсәнең дә булса бик аз булуы турында (күбрәк ашамлыклар тур.). *Көн буе эштә йөргән кешегә, башка замана булса, бу икмәк чәп итәргә дә җитмәс иде.* В.Нуруллин

**ЧӘПЧӘК** *и. к.* **чапчак**. *Бер чәпчәктә кымыз тулы ике чиләк.* В.Ильясов

**ЧӘ́П-ЧӘП** *иярт.* 1) Кул чапканда, авызны җиңелчә чапылдатканда һ.б.ш. очракларда барлыкка килгән тавышны белдерә. *Чәп-чәп чәбәкәй, кулларыбыз бәләкәй.* Юаткыч. *Ярмөхәммәт ике минлекне ике култык астына кыстырып, яңа төшкән сукмактан чәп-чәп атлап, бабасы артыннан кайта.* Р.Батулла

2) Дулкыннар ярга, бүрәнәгә, көймәгә һ.б.ш. бәрелгәндә, су өстенә суккан-да барлыкка килгән тавышны белдерә. *Дулкыннары ярга чәп-чәп бәрелеп, берсе-берсе белән серләшеп торган зур диңгезне карап тордым.* М.Гафури

◊ **Чәп-чәп керү** Мунчада чабыну. *Ә капитаннары ерак Татарстан яклары хуш исләрен алып килгән каен себеркеләрен, чәп-чәп керү өчен түгел, каютасын бизәү өчен тота ахры.* А.Хәсәнов

**ЧӘ́П-ЧӘП ИТҮ** *ф.* 1) Чәбәкләү, чәбәк-чәбәк итү. *Гөлчәчәк үзе дә күбекне тәннәренә чәп-чәп итеп чәбәкли, икәүләп көлешәләр.* Ф.Садриев

2) Мунча чабу (баланы). *[Әбием:] «Мунчада чәп-чәп итеп чыкканнан соң сөтле чәй эчү – үзе бер гомер», – дип, аны кыставын гына белә.* А.Хәсәнов

**ЧӘПЧЕК** I *и. диал. к.* **чәперчек**. *Аннан янә очып китә, тагын килеп куна, монда карый. Су кошы бу, чәпчек. Әллә ярга оясын корган инде?* Н.Хәсәнов

**ЧӘПЧЕК** II *и. диал.* Чытлык, кыланчык

**ЧӘПЧЕНҮ** *ф. сөйл. к.* **чәпчү** (*2 мәгъ.*). *Әби әйбәт булса, тулай торак дип чәпченүнең кирәге дә тимәс, бәлки.* М.Кәбиров. *– Ә нигә бармаска инде?! – дип чәпченде Шәмсенур.* Х.Ибраһим

**ЧӘ́П-ЧЕП** *иярт. к.* **чәп-чәп**. *Өй эчендә, чәп-чеп килеп, Кемнәрдер сөт эчәләр.* Г.Гыйльманов. *Кызларныкыдай кечкенә генә бөрмә сусыл иреннәре белән чәп-чеп битләреннән үпте.* Л.Ибраһим-Вәлиди

**ЧӘПЧЕТҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **чәпчү**. *[Шәйхи:] Сине чәпчетәсем килде.* Т.Гыйззәт. *[Госман:] Син таш йөрәкне чәпчетерлек ни булды?* А.Гыйләҗев

2) Чайпалдыру, читкә түгү. *Суны чәпчетү*

3) Таш атып, су өстендә вак дулкын боҗралары ясау. *Ай нурына коенган ак буа өстеннән кемнәрдер таш чәпчетәләр.* А.Гыйләҗев. *Кояш бик нык кыздыра башлагач, өсләрен чишенеп ташладылар да, чыр-чу килеп суга сикерделәр, бер-берсенә су сибештеләр, елга өстеннән җәенке ташлар чәпчеттеләр.* Н.Фәттах

4) Башка кеше белмәскә тиеш нәрсәне ялгыш әйтү, сөйләп ташлау; серне ачу

**ЧӘПЧҮ** *ф.* 1) Чайпылу, читкә түгелү. *Чиләк ятрылай булса, суы чәпчер, тулы чиләк чәпчемәс.* Мәкаль

2) Таш атып, су өстендә вак дулкын боҗралары ясаганда суга тиеп-тиеп китү. *Шуннан соң Габделкаюмның ташлары да су өстендә дүртәр-бишәр тапкыр чәпчи башлады.* М.Гали

3) *күч. к.* **чәпчетү** (*4 мәгъ.*). *Серне чәпчеп ташлау*

4) *күч.* Ярсу, ярсып китү, ярсып китеп, начар сүзләр әйтү. *[Хөрмәтулла:] Нәрсә әйтмәкче буласың болай чәпчеп?* А.Гыйләҗев. *Тик җиңгәсе генә чагып алмасын да җиңги чәпчемәсен...* В.Имамов. *«Табыш керә торган чак, товар килә, вакытым юк», – дип чәпчеде.* Г.Гыйльманов

**Чәпчеп алу** Аз гына чәпчү. *Җайлы кеше ул: бер чәпчеп ала да үз урынына утыра.* Г.Гыйльманов. *– Горурлыгың да юк инде синең, анакаем, һаман әтрәкәләм җыеп ятмасаң, – дип чәпчеп алды Анна түти.* Ф.Җамалетдинова

**Чәпчеп йөрү** Гел чәпчү. *Гыйльми, үзенең этлеге ачылудан куркып, чәпчеп йөрми, тикшертергә дә уйламый, димәк.* Ә.Моталлапов

**Чәпчеп китү** Кинәт чәпчү; чәпчи башлау. *Галим мулла, ничектер, Госманның: «Салихның шигырьләрен, язуларын гәзитәләрдә мактыйлар икән. Мин шуларны укыдым!» – дигәнен ишетеп калды да тагы чәпчеп китте.* Г.Ибраһимов. *– Дөрес түгел, – дип чәпчеп китте Наил.* З.Мурсиев

**Чәпчеп кую** Кинәт кенә чәпчү; бер тапкыр чәпчү. *– Килде шул әле менә! – дип чәпчеп куйды Бибинаҗия.* Ф.Яхин

**Чәпчи башлау** Чәпчергә тотыну. *Мәрьямнең дә сүзе бетмәгән икән әле. Әнә ул, чәчрәп, карчык каршысына килеп басты да чәпчи башлады.* М.Хәсәнов

**ЧӘРДӘКЛӘНҮ** *ф.* 1) Бик каты бәрелүдән яки сугылудан ватылыпсынып ваклану, вак-вак кисәкләргә аерылу. *Ишекнең ишек диярлеген калдырмаган, кабахәт! Аскы өлешенең дә,*

*өстенең дә фанерлары чәрдәкләнгән.* Д.Булатова. *Пыяла чәрдәкләнеп коелып төште.* И.Диндаров

2) Төрле юнәлештә чатнап китү, төрле зурлыктагы сыныклар барлыкка килү; сынып ваклану (сөяк тур.). *Уфа госпиталендә озак ятты. Аягы бик акрын төзәлде аның. Чәрдәкләнгән сөякләрне чүпләделәр, эрерәкләрен кире урыннарына җыйдылар.* З.Зәйнуллин. *Доктор, дәшми-тынмый гына, байның чәрдәкләнгән башын, изүләрен ачып, күкрәк тирәләрен караштыра...* М.Хәсәнов. *Аның кулы бик нык чәрдәкләнгән булып чыкты.* Ф.Садриев

**Чәрдәкләнеп бетү** Бик нык, күп урыннарда чәрдәкләнү. *Күк, ярылып, чәрдәкләнеп бетте.* Ф.Яхин

**Чәрдәкләнеп калу** Нindidер йогынтыдан соң чәрдәкләнү

**Чәрдәкләнеп китү** Кинәт чәрдәкләнү

**ЧӘРДӘКЛӘ́Ү** *ф.* Ватып-сындырып ваклау, вак-вак кисәкләргә аеру, яргалау. *Корал барлык сөякләрне чәрдәкли*

**Чәрдәкләп бетерү** Бик нык чәрдәкләү. *Мәгәр Дини, хәерсез, наганының түтәсе белән төеп, Габидулланың баш чүмечен чәрдәкләп бетергән, ди.* В.Имамов

**Чәрдәкләп ташлау** Тәртипсез рәвештә чәрдәкләү. *Тиен баласы әле җан биреп өлгермәгән иде, гәрчә бүре ядрәләре аны чәрдәкләп ташлаган, иләк ясаган булса да.* З.Хөснияр

**ЧӘРЕК** *и.* 1) Багана умартаның эченә рамнар беркетү өчен аркылы куелган агач. *Дәрхаль ун тавык пешереп китерде вә берничә чәрек китерде, янә башка тәгамны китереп җиткергәнче, тавыкларны һәммәсен ашады.* К.Насыйри

2) Көймә һ.б.ш.ларны эчтән ныгыту өчен куелган аркылы терәк; *русчасы:* **распорка**

3) *күч.* Чыдамлылык, түземлелек

4) *күч.* Характер ныклыгы

**ЧӘРЕКЛЕ** *с.* Түземле, чыдам. *Бигрәк чәрекле машина булды*

**ЧӘРЕКСЕЗ** *с.* Түземсез, чыдамсыз. *Тик коляскасы нинди бит аның: үзе ипсез, үзе чәрексез, ике-өч елдан тарала да төшә.* М.Маликова. *Сулыклар өсте боз белән капланды, тик әлегә ул чәрексез, ныклы түгел.* Зәй офыклары

**ЧӘРЕЛДӘВЕК** *с. к.* **чәрелдек**. *Агачлар арасыннан Әкмәлнең чәрелдәвек тавышы ишетелде.* А.Гыйләҗев. *Ул чәрелдәвек тавыш белән кычкырып җибәрде.* Р.Кәрами

**ЧӘРЕЛДӘ́Ү** *ф.* 1) Ачы нечкә тавыш белән кычкыру; чинау

2) Үзенә бертөрле тавыш чыгарып кычкыру (кайбер кошлар һ.б.ш. тур.). *[Акчарлаклар] яңадан һавага күтәреләләр һәм чәрелди-чәрелди күздән югалалар.* А.Шамов

3) *күч.* Тавышлану, ризасызлык белдерү. *Өммегөлсем дәррәү чәрелдәп кычкырды.* А.Гыйләҗев. *Адәм рәтле сөйләшүне белми, үзенә чит-ятлар якынлашудан өреккән көчек шикелле гел чәрелди генә.* В.Имамов

**Чәрелдәп алу** Бераз, аз гына чәрелдәү. *Барлык эшләгән эше – ак шәлен җилфердәтеп, әзер митингта, җыелышларда чәрелдәп алу.* З.Зәйнуллин

**Чәрелдәп җибәрү** Кинәт чәрелди башлау. *Хатын-кызлар колакларын учлары белән каплап чәрелдәп җибәрделәр, бала-чага елаша башлады.* М.Галәү. *Ул арада атыбыз аңа акаеп карады, мин тыела алмыйча: – Нишлисең инде?! – дип чәрелдәп җибәрдем.* К.Миңлебаев

**Чәрелдәп кую** Бер мәртәбә чәрелдәү. *Актаң чәрелдәп куя да куркуыннан шапылдап утыра.* Г.Каюмов. *Хатын-кызларның чәрелдәп куйган, саллы сүгенгән, акырып көлешкән тавышлары, кызып алган ирләрнең кычкырып-кычкырып сөйләшкәннәре яңгырап торды.* Л.Зөлкарнәй

**Чәрелдәп тору** Бертуктаусыз чәрелдәү. *Ачсам, астыбыздагы күрше каравыл кычкырып тора: «Өемне су басты, краннарыгызны ябыгыз, үлдембеттем!» – дип чәрелдәп тора.* Ш.Сагаутдинов

**Чәрелди башлау** Чәрелдәргә тотыну. – *Суның чисталыгы өчен бу шәһәрдә сез дә җаваплы түгелмени? – дип, тагын чәрелди башлаган тавыш ярты сүзендә өзелеп калды.* В.Имамов

**ЧӘРЕЛДЕК** *с. сөйл.* 1) Гел күп чәрелди торган, чәрелдәп сөйләшә торган. *Аны гына түгел, хәтта үзенең явыз дошманы Исламны да, икейөзле Илгизне дә, чәрелдек Кәрамны да, Тәзкирәне дә – барысын да, барысын да гафу итте.* Н.Фәттах. *Кипкән йөзле чәрелдек хатын үзенчә борчак чәчте.* С.Поварисов

2) Ачы һәм нечкә (тавыш тур.). *Бу күренеш белән мавыккан егетләр каяндыр астан ишетелгән чәрелдек хатын-кыз тавышына башта игътибар бирмәделәр.* М.Маликова. *Хатыннар арасыннан кайсыдыр чәрелдек тавыш белән сайрап куйды.* Г.Гыйльманов

**ЧӘРЕМ** *и. иск.* Күн

**ЧӘРКӘ** I *и. диал.* Балтыр, чәлтер. *Бәрә тәртәгә, тия чәркәгә.* Әйтем

**ЧӘРКӘ** II *и. рус* 1) *иск.* Исерткеч эчемлек эчү өчен борынгы савыт. *[Әхмәтҗан:] Син безгә ике чәркә сыра, ярты штоф кумышка китер.* М.Гали

2) *сөйл.* Рюмка. *Ул сабыр итәргә булды, җан азыгы санап, бер-бер артлы ике чәркә коньяк эчте, шешәне почмакка ыргытты.* А.Гыйләҗев

**ЧӘРМӘК** *и. иск.* Каеш, чи каеш

**ЧӘРПӘЛӘНҮ** *ф. диал.* 1) *к.* **чәрдәкләнү**. *Түбән Оч Зәбир бабайның карчыгы Мәгърифә әби малайның чәрпәләнгән сөякләрен урынына җыйнаштырып, тиресе өстеннән кабык белән тарттырып бәйләп куйган иде куюын.* З.Зәйнуллин

2) Яргалану, сырлар барлыкка килү. *Картайгач, маңгае чәрдәкләнгән*

**ЧӘРПӘЛӘ́Ү** *ф. диал.* 1) Чәрдәкләү

2) Яргалау, ергалау, сызгалау. *Ярыла торган пуля Вәлиевның яңагын чәрпәләгәч, ул биш ай госпитальдә газапланып ята.* Өмет

**ЧӘРТӘП** *и. диал.* Известь. *Ул эшләнгән гидравлик чәртәп һәм цемент кату теориясе бүгенге көндә дә, нигездә, үзенең актуальлеген югалтмаган.* Төзү материаллары. *Чәртәп онын иң күп җитештерүчеләр – Минзәлә, Чирмешән һәм Чистай районнарында урнашкан карьерлар.* Фән һәм тел

**ЧӘ́Р-ЧӘР** *ияpт.* Ачы итеп кычкырганда, артык югары тавыш белән сөйләшкәндә барлыкка килгән тавышны белдерә. *Әхсән торып басты, каршысында чәр-чәр кычкырынып торган хатынны читкәрәк этәргә теләгәндәй, кулын сузды.* М.Маликова. *Фельдшер чәр-чәр килде.* Ф.Яруллин

**ЧӘРЧӘРЛЕ** *и.* Балалар уенының бер төре; йорт-йортлы уены

**ЧӘРШӘМБЕ** *и. фар.* Атнаның сишәмбе белән пәнҗешәмбе арасындагы өченче көне. *Кичә әйтте бит, чәршәмбе дәресләрем юк, диде, балыкка барам, диде.* Л.Лерон. *Иртәгә чәршәмбе.* А.Фәләх

**ЧӘТЕЛДӘВЕК** *с. к.* **чәтелдек**

**ЧӘТЕЛДӘҮ** *ф. сөйл.* Телләшү, каршы әйтү, усал итеп сөйләшү. *Ул арада каяндыр кәтүктәй бер кеше килеп чыкты да нечкә тавыш белән чәтелдәде.* Л.Лерон

**ЧӘТЕЛДЕК** *с.* Бик үткен, чая телле (гадәттә хатын-кыз яки бала-чага тур.)

**ЧӘТЕРДӘ́Ү** *ф. диал. к.* **чәтелдәү**. *Гөлкәй, оялуыннан, Чулпанның җиңеннән тартып, китәргә чамалый башлаган иде дә, кыз чәтердәп чыкты.* Х.Ширмән

**ЧӘТЕРТӘН** *и. диал.* 1) *к.* **чәтелдәвек**. *Сөем кыз гаять чәтертән булып үсте, әче итеп сызгырыр иде, маймылдай җитез иде, ат сыртына ябышып үскәндәй хәтәр җайдак булды.* Р.Батулла

2) Эшкә җитез, чая, үткен. *Кияү бик тынгысыз булып чыкты: ашарга да пешерде, чәтертән кебек керен дә уды, идән дә юды.* Ф.Садриев

**ЧӘТЕ́Р-ЧӘТЕР** *ияр*т. *к.* **чәт-чәт** (*1 мәгъ.*). *Аның да чәтер-чәтер ызгышуы.* Н.Кәримова

**ЧӘТЛӘКИ** *и. диал. к.* **чүрәкәй** II. *Җәен бергә су коенабыз, бергә чәтләки уйныйбыз, шар сугабыз.* Ш.Маннур

**ЧӘТНӘБИ** *и. диал.* **1.** Сүзгә бик оста һәм үткен кеше; җитез, чәчрәп торган кеше. *«Класс белән колхозда калыйк», – дип, иң элек шул чәтнәби безәнләп йөрде.* Ф.Садриев

**2.** *с. мәгъ.* Чәчрәп торган, үткен, сүзгә оста. *Нindидер бер кылтык чәтнәби почтабикәнең кыланмышына карап торыр чак түгел.* Ф.Латыйфи

**ЧӘТ-ЧӘТ** *ияр*т. 1) Уч белән берәр шома өслеккә, ялангач тәнгә һ.б.га суккалаганда барлыкка килгән тавышны белдерә. *Чәт-чәт итеп, минлекләр алмаш-тилмәш җилкәгә куна башлады.* Р.Батулла

2) Усал итеп, өздереп, чатнатып, кыю итеп сөйләү рәвешен белдерә. *Склад будкасына ник кергәнемә үкенердәй булдым: кызларның теле телгә йокмый – ләтчә кебек, чәт-чәт итеп кенә торалар.* Р.Вәлиев. *Яңа Бистәнең чәт-чәт килеп торган Зөлхәбирәсен акыллы сүзе белән урынына утыртты да куйды.* С.Зыялы

**ЧӘҮКӘ** *и.* Каргачалар семьялыгыннан соры башлы, кара каргадан кечерәк кош; *русчасы*: **галка**. *Килеп тулган карга, чәүкә, чыпчык...* И.Гыйләҗев

**ЧӘҮКӘ БАШЫ** *и. диал.* Тукранбаш, клевер. *Июнь-июль айларында бу җирләрдә актамыр, чәүкә башы шикелле үләннәр кеше күмелерлек булып үсәләр.* З.Бәшири

**ЧӘҮКӘ́-ЧӘҮКӘ** *с. сөйл.* Бик эре бөртекләрдән гыйбарәт. *Шул арада чәүкә-чәүкә кар ява башлады.* Ш.Камал

**ЧӘҮЧӘЛӘК** *с.* Түземсез, ашыгучан, кабаланучан // Юкка-барга борчылучан, тынгысыз, бәргәләнүчән, көйгәнәк. *Әнисе элеккегә караганда да кырыс, чәүчәләк булса да, Гөлзиләнең күңеле кителмәде.* М.Кәбиров. *Урынын ут алган кешедәй тынгысыз бу чәүчәләк ханымның шулай тыныч кына тамаша кылып утыруы гайре табигый хәл иде.* М.Әмирханов

**ЧӘҮЧӘЛӘКЛӘНҮ** *ф.* Түземсезләнү, ыгы-зыгы килү // Юкка-барга борчылу; гасабилану, бәргәләнү. *Шулай да артык акырып-бакырып, чәүчәләкләнеп, елап-ыңгырашып килмәде якты дөньяга өзелеп-тилмереп көткән бу бала.* С.Поварисов. *Димәк, өендә тәртип: кием-салым юылган, җәмәгате юк-барга чәүчәләкләнеп, чокчып торучылардан түгел, туклану мәсьәләсе дә үз югарылыгында.* Р.Кәрами

**ЧӘҮЧӘЛӘКЛЕК** *и.* Чәүчәләк булу үзлеге, гасабилык

**ЧӘҺАРШӘМБЕ** *и. фар. иск. кит. к.* **чәршәмбе**. *Бүген чәһаршәмбе, шуңа күрә озатачак никруты булган йортларда бүген аерым бер хәзерлек, аерым бер хәрәкәт бара.* Г.Ибраһимов

**ЧӘҺРӘ** *и. фар. иск.* Чырай, йөз. *Кайчандыр искиткеч гүзәл булган чәһрә яман тимгелле, күңел кайтаргыч бер ит бүкәненә әйләнгән.* Р.Батулла

**ЧӘЧ** *и.* 1) Кешенең башында үсә торган, мөгез матдәдән гыйбарәт бик нечкә җеп сыман төк. *Коелган чәч агармый.* Ш.Галиев. *Кеше йөзе – гаҗәеп бер табигать табышмагы: бернинди җыерчык юк, бер генә ак чәч бөртеге күренми, ә менә бахырның бик нык таушалган, йончыган булуы ярылып ята.* З.Мурсиев

2) Кешенең башында үсә торган шундый төкләрнең барысы. *Ул беренче мәртәбә быел кыш озын чәч йөртә башлады...* А.Гыйләҗев. *Кайбер кешеләр яртылаш агарган чәч белән дә шактый гомер йөриләр.* В.Нуруллин

3) Шундый төкләргә охшаган нәрсә. *Бервакыт күрше басуда ике хатын-кыз кукуруз чәче җыя.* Безнең гәҗит

◊ **Чәче чәчкә бәйләнү** Өйләнүөйләнешү язмыштан килә, дип санау турында. *Күрәсең, чәчләре чәчкә үк бәйләнеп туганнардыр инде – кыз башта икеләнебрәк торса да, соңыннан риза булган.* В. Нуруллин. **Чәчең дә җитмәс** Берәр нәрсәгә бик күп чыгым кирәк булганда яисә берәр нәрсәне җиткереп булмаганда әйтелә. *Ел тәүлегенә чутлап чыгарсаң, аңа бит башыңдагы чәчең дә җитмәс!* Г.Бәширов. **Чәчләрне йолку** Нәрсәгә дә булса бик нык үкенү, өметсезлектән нишләргә белмәү. *Гәрдән кулакның кызы Гөлсем хәзер чәчләрен йолкый-йолкый үкерә, ди...* В.Имамов. **Чәч төпләренә кадәр** Бик нык, тоташ. – *Минем кияүгә барасым килми, – диде Сусылу, чәч төпләренә кадәр кызарынып.* М.Хәбибуллин. **Чәчләр үрә тору** Бик нык курку яки гаҗәпләнү. *Әмма... бер минуттан соң инде чәчләрем үрә торды, телдән калдым, чөнки без Нәфисәне түгел, ә аның... анасын – Шәрифә карчыкны урлаганбыз икән...* А.Шамов

**ЧӘ́Ч АЛУЧЫ** *и.* Чәчне, сакалны кыру яки берәр төрле рәвеш биреп кырку һәм буяу, тарау эше белән шөгыльләнүче оста; парикмахер. *Минем чәч алучым да Рита исемле ассирияле иде.* Г.Гомәр

**ЧӘЧӘГАШАР** *и. зоол.* Пластинкамыеклылар семьялыгыннан үсемлекләрнең чәчәкләре белән туена торган корт; *русчасы*: **жук-цветоед**. *Чәчәгашар чирүенә чәчәк ни дә, чәкән ни.* З.Мансуров

**ЧӘЧӘК** I *и.* 1) Ачыгорлыклы һәм ябыгорлыклы үсемлекләрнең таҗ яфракчыкларыннан, серкәч белән җимешлектән гыйбарәт үрчү әгъзасы. *Роза чәчәге таҗына сары сандугач баласы кунган.* Г.Сабитов. *Сирень чәчәгенең бишлесен... Табам диеп озак эзләдем...* В.Мәхмүтова

2) Шундый үрчү органы булган үләнчел үсемлек. *Язлар килер чәчәк исе бөркеп.* А.Алиш. *Гаҗәеп чәчәк иде ул: кызыл, ак, шәмәхә, зәңгәр таҗларга төренгән гөлчәчәк күз явын алырлык иде.* А.Әхмәтгалиева

◊ **Чәчәк аттыру** Канәгатьлек бирү, нык куандыру, рәхәт китерү. *Балкып янган гөлләре күңелне хозурлый, җанының чәчәк аттыра, яшәү чаткылары, гүзәл өметләр уята, матурлык хисләре белән чолгап ала.* Н.Хәсәнов. **Чәчәк ату** 1) Чәчәк барлыкка китерү, чәчәкләнү (үсемлекләр тур.). *Аңа калса, койма буендагы гөлҗимеш әле һаман чәчәк атып утыра кебек.* Г.Әпсәләмов; 2) Үсешнең югары дәрәҗәсенә җитү; күтәрелеш хәленә килү. *Борынгы Рим дәүләтенең чәчәк ату чоры*; 3) Канәгатьләнү, рәхәтлек тою. **Чәчәк кебек чагы** *к.* **чәчәк чагы**. **Чәчәк чагы** Кемнең дә булса физик һәм рухи көчләренең иң үскән чагы; яшь һәм көчле чагы. *Егерменче язым – чәчәк чагым!* Р.Сәйфетдинов. *Үзенең яшьлеген, үзенең чәчәк чагын, кадерле чагын, үзе өчен кадерле булган чакларны сагынып кайткан.* Н.Акмал

**ЧӘЧӘК** II *и.* 1) Тиредә ахырда шадрага әйләнәчәк үлекле тимгелләр барлыкка китерә торган йогышлы авыру. *Татарларның фикеренчә, балага чәчәк чыккач, аның зур чәчәкләрендә чәчәк анасы тора.* К.Насыйри. *Чәчәк авыруыннан соң калган биш-алты бөртек*

*шадрасы аның йөзен аз гына да ямьсезләми, киресенчә, аңа ниндидер үткенлек, батырлык, гайрәтлелек төсе бирә иде кебек.* Г.Әпсәләмов

2) Шул авыру вакытында тәндә барлыкка килгән тимгел. *Төшеңдә тәнең ала булган, яисә тәнеңә чәчәк чыккан дип күрсәң, мөшкел эшләрең ачылырлар, диелә «Төхфәтел-мөлек» китабында.* Ф.Яхин

3) Шул авыруга каршы ясалган прививкадан тәндә калган эз

◊ **Чәчәк салу** Чәчәк авыруына каршы прививка ясау. *[Гөлчирә:] Юк, Каргалы волостена, балаларга чәчәк салырга барышым.* Т.Гыйззәт. *Мөдир үзе бозык булгач, пунктның башка медицина эшчеләре дә: фельдшер Николай Яковлев, акушерка Хәдичә Таһирова, санитарка Мәрьям Галиева, чәчәк салучы Петров та эшкә салкын карарга гадәтләнгәннәр.* Г.Кутуй

**ЧӘЧӘ́К КӘБЕСТӘ** *и.* Укмаш чәчәктән гыйбарәт башы ашамлык булган берьеллык яшелчә үсемлек; кәбестәнең бер төре

**ЧӘЧӘ́К КОҢГЫЗЫ** *и. к.* **чәчәгашар**. *Ул агачларны чәчәк коңгызы һәм туфракта кышлый торган башка корткычлардан саклый.* Сөембикә

**ЧӘЧӘКЛӘНДЕРҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **чәчәкләнү**. *Кояшның җылыткан җылысы никадәр ихластан булса да, агачларны яфракландырырга, гөлләрне чәчәкләндерергә көче җитмәгәнгәме, кояшның нуры никадәр матур, никадәр йомшак булса да, --- бу көннәрнең җылысын карчыклар җылысына, бу көннәрнең матурлыгын карчыклар гүзәллегенә охшатканнар.* Г.Исхакый. *Җиң очларын чәчәкләндерү*

2) *күч.* Үсешнең югары дәрәҗәсенә күтәрү. *Чөнки без милли-мәдәни мохтариятымыз бер халык, бер милләт үзенең байлыкларын, үзенең бөтен хаҗәтләрен кирәге кадәр чәчәкләндереп яши алмый дип ышанамыз.* Г.Исхакый

**Чәчәкләндереп кую** Алдан ук чәчәкләндерү

**ЧӘЧӘКЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **чәчәкләү**

2) Үсемлектә чәчәк (I) барлыкка килү, чәчәк ачылу; чәчәк ату. *Урманның бер почмагында, аулакта гына чәчәкләнгән бер гөлнең кисәктән генә чәчәге шиңә башлады, һәм аз гына вакыт эчендә яртысы шиңеп тә бетә язды.* Г.Тукай

3) Чәчәкләр белән каплану, күпләп чәчәкләр үсү. *Әнә шул Иделнең чәчәкләнеп тармакланган бер урынында, гүя чык тамчысы булып, җемелдәп, Астрахань дигән шәһәр тора.* Р.Фәйзуллин. *Язлар килә, Чәчәкләнә тугайкырлары.* Г.Мортазина

4) *күч.* Үсешнең югары дәрәҗәсенә күтәрелү. *Йөрәгемдә ялкынланып тора Чәчәкләнгән сөю хисләрем.* В.Галиев

5) *күч.* Матурлану, чибәрләнү. *Нәгыймә тагын чәчәкләнде.* Г.Ибраһимов

6) *күч.* Берәр кием, тукыма һ.б.ш.ның кырыйлары таушалып, җепләре чыга башлау, төрле якка чыгып тору

**Чәчәкләнә башлау** Чәчәкләнергә тотыну. *Саз үләннәре иртәрәк чәчәкләнә башлаган, кәҗә таллар да яшелләнә.* М.Рәфыйков

**Чәчәкләнеп калу** Чәчәкләнергә өлгерү яки берәр нәрсәдән соң чәчәкләнгән хәлгә килү. *Су сипкәндә үсәр гөлләреңә, Чәчәкләнеп калсын йөрәгең.* В.Галиев

**Чәчәкләнеп китү** Кинәт чәчәкләнү; җае белән чәчәкләнү. *Тормышлары чәчәкләнеп китте дигәндә генә...* Р.Низамиев

**Чәчәкләнеп кую** Тиз арада чәчәкләнү. *– Кирәк икән, без аны җыршигырь белән дә чәчәкләндереп куярбыз! – диде Гайнулла абзасы, шешәне куен кесәсенә яшереп.* Д.Гыйсметдин

**ЧӘЧӘКЛӘ́Ү** *ф.* 1) Чәчәк белән бизәү, чәчәк төшереп бизәү. *Җир дә күмәкләп, илне чәчәкләп, Гөлгә әйләнер.* М.Җәлил. *Кояш нурлары күзләрдә чагыла, талгын җилләр битләреңне иркәли, җылы яңгырлар дөньяны чәчәкләп яшеллеккә төрә...* Р.Фәйзуллин

2) *күч.* Сөйләгәндә, язганда артык матурлау, бизәкләү

**Чәчәкләп бетерү** Бик нык чәчәкләү

**Чәчәкли төшү** Тагын да ныграк чәчәкләү

**ЧӘЧӘКЛӘЧ** *и. зоол.* Черек агачта яши торган бик ачык төстәге коңгыз; *русчасы:* **цветолюб**

**ЧӘЧӘКЛЕ** *с.* 1) Җимеш бирү әгъзалары чәчәк рәвешендә булган, чәчәк ата торган (үсемлекләр тур.).

2) Хәзерге моментта чәчәк атып утырган // Билгеле сыйфатлы чәчәге булган. *Тамчыгөлләрне халык ярата, тик монда алар бөтенләй дә башкача: янып торган зур чәчәкле һәм һәрбер тәрәз төбен балкытып торалар.* А.Нәҗми

3) Чәчәкләр белән капланган, чәчәкләр күп үскән (болын, кыр һ.б.ш.). *Шау чәчәкле бу утрауларда халык күп яши...* А.Тимергалин. *Ирексездән ул сине, хыял канатларына күтәреп, үткәннәргә, алтын яфраклы көзгә, чәчәкле киң болыннарга илтеп ташлый.* А.Мансуров

4) Бизәк итеп чәчәкләр төшерелгән, чәчәк рәсеме белән бизәлгән. *Эре чәчәкле тюль сайлаганда, автобазадагы Софья Матвеевна әйтмешли, иптәш Сәйдәшев бер-бер хатын-кыз белән киңәшмичә калмагандыр әле, дигән уй күңелемне тагын җылытты.* А.Тимергалин. *Мич аралыгында кызыл чәчәкле чаршау бар иде.* А.Әхмәтгалиева

5) *күч.* Артык бизәлгән, чуарланган (стиль, сөйләм тур.). *Аның сорауларын төрле чәчәкле сүзләр күмеп китте.* Г.Бәширов

**ЧӘЧӘКЛЕК** *и.* Бакчада, паркта һ.б.ш. җирдә чәчәк утыртылган түтәл; чәчәк үсә торган аерым бакча, гөлбакча. *Дувал буендагы куаклар арасында чикерткәләр сайрый, ишегалды уртасындагы чәчәклек өстендә күбәләкләр уйный.* Т.Әйди

**ЧӘЧӘКЛЕ́-ЧУКЛЫ** *с.* 1) Чуар, бизәлеше артык күп булган, зәвыксыз. *Виолетта алдагы чәчәкле-чуклы сумкасының озын бавын җиңенең өстенәрәк шудырды да, йомры ияген чөя төшеп, тураебрак басты.* М.Маликова. *Алар өчен иң матур кием – чәчәкле-чуклы күлмәкләр.* Безнең гәҗит

2) *күч.* Ярарга тырышып, кәнфитләнеп әйтелгән, артык төче // Әдәби осталык ягыннан түбән сыйфатлы, күп сүзле булып та мәгънәсен бирә алмаган. *Халыкка әйтер сүзе булган язучы газета-журнал биргән мөмкинлекне андый вакытта да урынлы файдаланыр, күптән мәгълүм фикерләрне чәчәкле-чуклы сүзләргә төреп кенә яңартырга маташмас, һәр вакыйганы үзенчә күрә белеп, яңача тасвирлый алыр.* И.Низамов

**ЧӘЧӘ́К САБЫ** *и. бот.* Сабакның чәчәк урнашкан өлеше; *русчасы:* **цветоножка**. *Чәчәк чәчәк сабында үсә, чәчәк сабы чәчәк түшәге ясап киңәя, һәм анда чәчәкнең башка өлешләре формалаша.* Биология

**ЧӘЧӘ́К ТАБАНЧАСЫ** *и. бот.* Барлык чәчәкләре бер яссылыкта урнашкан укмаш чәчәк; *русчасы:* **щиток цветка**

**ЧӘЧӘ́К ТИРӘЛЕГЕ** *и. бот.* Чәчәкнең серкәч белән җимешлекне тышкы яктан уратып алган өлеше; *русчасы:* **околоцветник**. *Касә һәм таҗ икесе бергә чәчәк тирәлеге төзиләр.* Ботаника

**ЧӘЧӘ́К ТӨБЕ** *и. бот.* Чәчәк сабының җимшәнне тотып тора торган өле-

ше; *русчасы*: **цветоложе**. *Җиләк яфрагы, сабагы һәм чәчәк төбе составына микробларга каршы көрәшә торган матдәләр, фитонцид, С витамины һәм флавоноидлар керә.* Мәйдан

**ЧӘЧӘ́К ТӨПЛЕГЕ** *и. бот. к.* **кәшәнкә**; *русчасы:* **плюска**

**ЧӘЧӘ́К ТУЗАНЫ** *и. бот.* Серкә. *Ыштан балагын экчә тыгып кигән ак оекбашларына чәчәк тузаны кунып, билчән уралып, бакра сырышып беткән, әйтерсең Юлкотлы яланнарын үзе белән ияртеп кайта ул...* Ә.Еники

**ЧӘЧӘКЧЕ** *и.* 1) Чәчәк үстерүче, чәчәкчелек белгече. *Чәчәкче Бариның йөрәге түзмәде, ул: – Сез нишлисез? Кагылмагыз чәчәкләргә! – дип кычкырды.* Р.Батулла

2) Чәчәк сатучы

**ЧӘЧӘКЧЕЛЕК** *и.* Хуҗалыкның чәчәк үстерү белән шөгыльләнә торган тармагы // Чәчәк үстерү шөгыле. *Алар физкультура занятиесендә дә булалар, чәчәкчелек, яшелчәчелек белән шөгыльләнәләр, шашка уйныйлар, үзешчән сәнгатьтә һәм иҗатта да үзләрен күрсәтәләр.* Яңа Чишмә хәбәрләре

**ЧӘЧӘЛӘНҮ** *ф. диал.* Артык вакчылланып бәйләнү, вакчылланып тиргәү. *– Бар да чәнчелеп китте... – диде ул, чәчләрен йолкырдай чәчәләнеп.* М.Хәсәнов. *Нидер уйлап торгач, Ләйсән, тагын яшүсмерләрчә чәчәләнеп, гомумиләштереп сөйли башлады.* Б.Камалов

**Чәчәләнә бирү** Чәчәләнүен дәвам итү. *Салтанатбикә, иренең әле бер, әле икенче ягына чыгып, һаман чәчәләнә бирде.* Ә.Мохтар

**ЧӘЧӘМӘ́ ЮТӘЛ** *и. к.* **бума ютәл**

**ЧӘЧӘН** I *и. диал. к.* **чичән**. *Күпме чәчән җиһан кичте хаксызга, Күпмеләре эзсез гаип булдылар.* И.Юзеев. *Чәчән бабайларның кайтавазы Яңгырыймы бүген безнең җанда?..* Г.Морат

**ЧӘЧӘН** II *с. иск. диал.* Көяз, пөхтә, фырт. *Симез – күркәм, бай – чәчән.* Мәкаль

**ЧӘЧӘНЛӘШҮ** *ф. диал.* Чәчәнгә әйләнү, үткенләнү, тапкырлану. *Эчүнең исәбе-саны булмады, кымыз күбрәк китерелгән саен, башлар җиңеләя, күзләрдә ут уйный, телләр чәчәнләшә бара иде.* Г.Ибраһимов

**ЧӘЧӘНЛЕК** *и. диал. к.* **чичәнлек**. *Акын туктамады, һаман төрле көйгә салып җырлый бирде: бүгенге хәсрәтне әйтү өчен чәчәнлек кирәк имәс.* Г.Ибраһимов

**ЧӘЧӘТҮ** *ф. йокл. юн. к.* **чәчәү**. *Ә бу вакытта ут балок эчендә дә яна иде инде, ачы төтен чәчәтә, тамакларны буа башлады.* И.Хуҗин

**ЧӘЧӘ́Ү** *ф.* Сулыш юлына берәр нәрсә эләгүдән сулыш алу кыенлашу; төелү, кылкыну, ялгыш юлга китү. *Аракысы ялгыш юлдан киттеме, башка сәбәпме, Җәмил чәчәде, буылып-буылып ютәлләргә кереште.* Н.Әхмәдиев. *Ул чәчәде, сулыш ала алмый интекте, кызарынып-бүртенеп йөткерде.* М.Маликова

**Чәчәп бетү** Хәл чәчәүгә барып җитү. *Улының аяклары пешкәнен ишетеп, әллә кайдагы Кызыл Саз басуыннан йөгереп кайта торгач чәчәп беткән әнисенең кыяфәте Камилнең әле дә күз алдында...* Ф.Абдуллин

**Чәчәп җибәрү** Кинәт чәчәү. *Батима карчык, тамагына азык утырган сыман, чәчәп җибәрде, тамагын кыргалый башлады.* Н.Фәттах

**Чәчәп кую** Бер тапкыр чәчәү. *Усман карт бу сораудан чәчәп куйды.* А.Хәйретдинова

**Чәчи башлау** Чәчәргә тотыну. *Ләкин бала шунда ук чәчи дә башлады...* Ә.Еники. *– Баҗа каршында чисымны күтәрдегез! – дип куанды Габсаттаров, чәчи башлаган Зөбәирнең аркасына ястык кадәрле кулы белән сугып.* Н.Әхмәдиев

**Чәчи язу** Чак кына чәчәми калу. *Шунда ук чүмечкә капланды, чәчи язды, бөтен бите җыерылып килде һәм, борыны пешкән мәчедәй пырых-пырых итеп, башын чайкап торды...* Ә. Еники

**ЧӘЧБАГ** *и. иск. к.* **чәчүргеч**

**ЧӘЧБАЙ** *и. сөйл. к.* **чәчби** (*1 мәгъ.*). *Нурислам, тиздән пенсиягә чыгып, чыннан да «бабай» исемен күтәрергә хаклы була торып, чәчбай үсмерләр белән стадион юлын таптасын, шак-шок домино сугып утырсынмы*? Р.Төхфәтуллин

**ЧӘЧБӘЙ** *и. бот.* Кыяклылар семьялыгыннан күпьеллык үлән; тутык үләне; *русчасы:* **вейник**. *Урман алларында үлән үсемлекләрдән күпьеллык үләннәр – чәчбәйләр, сарут, кындырак һ.б. үсә башлый.* Җир һәм туфрак

**ЧӘЧБИ** *и. сөйл.* 1) Озын тузгыган чәчле кеше (ешрак хатын-кыз тур.) *Җәза җансакчысы Хасдай тик ул чәчби белән озак тора алмады, тангутларга яу баргач, биек кирмән дивары буенда ятып калды.* М.Хәбибуллин

2) Гомумән хатын-кыз. *– Сиңа ияргән яулыклы чәчби кем ул? – диде Гыймран, ераклашкан Алиягә табан каерылып.* Н.Гыйматдинова

**ЧӘЧВАН** *и. фар.* Пәрәнҗәнең йөзне каплый торган, кара кылдан үрелгән пәрдәсе. *Башта үксегән тавыш ишетелде, аннары сак кына пәрәнҗәнең чәчваны ачылды.* Т.Әйди

**ЧӘЧЕ** *и. диал.* Юеш ашлыкны киптерү өчен, агачлардан ясалган корылма, таган, шеш

**ЧӘЧЕЛЕ́П-ТУЗЫЛЫП** *рәв. сөйл. к.* **чәчелеп-түгелеп**. *[Габтелмән:] Ындыр тирәсендә чәчелеп-тузылып ята торган салам гына. Әрәм-шәрәм булмасын дип җыйдым.* Р.Ишморат

**ЧӘЧЕЛЕ́П-ТҮГЕЛЕП** *рәв. сөйл.* Читкә чәчелеп, таралып, төрле җиргә таралып китеп. *Ул аңлап алган иде инде: урман эчендә йөргәндә, чүлмәктәге бөтен хәзинә чәчелеп-түгелеп беткән...* Г.Гыйльманов

**ЧӘЧЕЛЕШҮ** *ф. урт. юк. к.* **чәчелү**. *Яссы тау битләрендә чәчелешеп көн иткән, уйнаган, арлы-бирле чабышкан байбакларны беркем дә борчымый, тыймый, аларга янамый.* А.Хәсәнов

**ЧӘЧЕЛМӘЛЕ** *с. сөйл.* Бер ноктадан тирә-якка таралган, уртадан төрле якка юнәлгән. *Сул яктагы дача тирәсендә, агачлыклар төркеменең өстендә, ромашка чәчәге төсле чәчелмәле зур бер тәгәрмәч күтәрелеп тора.* Ш.Камал

**ЧӘЧЕЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **чәчү**. *Кайчандыр сугышка кадәр киндер ашы, җитен чәчелеп, чөгендер, суган, мал тормасы утыртылып, үзендә дөрес чәчү әйләнеше саклаган җир.* А.Хәлим. *Уналты мең гектарда чәчелгән бодай, тары, көнбагыш өлгереп килә.* А.Хәсәнов

2) Түгелеп, төрле җиргә барып төшү, тәртипсез таралып китү. *Аяк астына чәчелгән юка бәрәңге кабыклары бөтерелеп-бөтерелеп килүче әкәмтөкәмнәр булып күренәләр, озак карап торганга алар кыймылдыйлар, куркыталар...* А.Гыйләҗев. *– Менә! – диде малай, өстәлдә чәчелеп яткан әйберләргә күрсәтеп.* А.Тимергалин

3) Нинди дә булса сыеклыкның бик вак кисәкчекләре, тамчылары таралу, читкә чәчрәү. *Күзләре яман акайган, авызыннан төкрекләре чәчелә, сары сакал бер аска, бер өскә сикереп бии.* И.Салахов

4) *сөйл.* Берәм-берәм егылу, егылып төшеп калу. *[Вәли:] Ибрай абый атып җибәргән иде, атлары алды да китте. Чак кына аумадылар. Кайсылары чәчелеп калды.* М.Фәйзи

5) Төркемләп яки берәмләп төрле якка китү, таралу. *Чабаталары белән кар өстендә сырлы эз калдыра-калдыра, җир казучылар су алгычны казыр өчен чәчелгәннәр.* А.Алиш

6) Төрле юнәлештә урнашу, урнашкан булу; төрле-төрле җирдә булу. *Күк йөзенә эреле-ваклы йолдызлар чәчелгән иде.* А.Нәҗми

7) *күч.* Төрле якка яки кая да булса таралу, җәелү (яктылык, нурлар тур.). *Аның кыргыйланган күзләреннән очкыннар чәчелде.* А.Нәҗми

8) *сөйл.* Күпләргә билгеле булу, таралу. *[Фәйзулла:] Бу картның даны юккарак чәчелгән икән.* Г.Ибраһимов. *«Мин дә мин!» дип чәчелеп йөрмәсә дә, Җәүдәтнең күңелендә аз гына масаюга охшаган хис тә туа башлаган иде.* А.Гыйләҗев

9) Бер эшкә игътибарны тупламыйча, бер үк вакытта төрле эшләр белән шөгыльләнү. *Чәчелеп-чәчелеп язарга туры килә.* А.Хәсәнов

10) Таркаулану, тәртипсез хәлгә килү, чуалу. *Ялкынлы серле күзләрең күреп, булган акылым чәчелде инде.* А.Нәҗми

**Чәчелеп бетү** Бөтенләй, күп булып чәчелү. *Өч тәүлек буена юлда берберебез белән танышып, хәтта дуслашып өлгергән якташлар тегендә-монда чәчелеп бетте.* В.Нуриев. *Сәүбәннең күз алдында аның балачак образы, күк томанга әверелеп барып, салмак кына дулкынлана, җәелә һәм, ниһаять, таркалып чәчелеп бетә.* Г.Гыйльманов

**Чәчелеп калу** Чәчелергә өлгерү. *Җир әйләнә бит ул, әйләнә, егылып китмәс өчен, чәчелеп калмас өчен тарту көче – дуслык кирәк...* А.Гыйләҗев

**Чәчелеп китү** Кинәт чәчелү. *Бик чәчелеп китмичә генә, сүзгә Гомәр оста да кушылды.* В.Имамов

**Чәчелеп тору** Һәрвакыт чәчелү; чәчелгән хәлдә булу. *Баланы күрергә килүчеләр хәйран булдылар: аның йөзеннән үзенә бертөрле илаһи нур чәчелеп торыр иде.* Ф.Яхин. *Егетнең күзләреннән очкыннар чәчелеп тора иде.* Р.Сәгъди

**Чәчелеп яту** *сөйл. к.* **чәнчелеп тору**. *– Менә! – диде малай, өстәлдә чәчелеп яткан әйберләргә күрсәтеп.* А.Тимергалин. *Кыз җирдә чәчелеп яткан әфлисуннарга күрсәтте.* А.Мансуров

**ЧӘЧЕМ** *и. этн. к.* **гүр садакасы**. *--- аның алып куйган кәфенлеге дә, чәчеме өчен җыеп торткан тәңкәләре дә, гәүдәсен ләхеткә куючылар өчен саклап килгән сөлгеләре дә бар иде...* Ә.Еники

**ЧӘЧЕМЛЕК** *и. этн.* **1.** Гүр садакасы тарату йоласы. *Кабер чәчемлеге өчен дип җыйнап килгән ике көмеш тәңкә белән бакырларны, нинди кара көнгә төшсә дә, тапмаслык итеп, әллә кай эчкә яшергән.* Г.Ибраһимов

**2.** *с. мәгъ.* Чәчемгә дип билгеләнгән. *Чәчемлек акча*

**ЧӘЧЕРГӘЛӘНЕП** *рәв. диал.* Бик усалланып; ачыргаланып. *[Этләр] бик нык чәчергәләнеп өрә-өрә Әхмәт тирәсендә әйләнгән арада, ул аларның берсенә аягы белән нык кына тибеп җибәрде.* Ш.Камал

**ЧӘЧКАП** *и. этн.* Хатын-кызларның чәчен һәм толымнарын каплый торган тукымадан ясалган баш киеме. *Иске чәчкап күрә дә ул Мөһер суга: Тол хатын!* Г.Гыйльманов. *Баш артына, чәч толымнары өстенә тәңкәләр белән бизәлгән, очына чулпы тагылган чәчкап яки чәчүрем куйганнар, муенга исә мәрҗәннәр белән чигелеп, тәңкәләр тезеп эшләнгән тамакса кигәннәр.* Ф.Баязитова

**ЧӘЧКӘ** *и. к.* **чәчәк**. *Яз саен ак сирень чәчкә аткан мәлдә, Наилә бер-бер артлы тупылдап торган баһадир уланнар алып кайтты.* А.Хәйретдинова. *Син ошаткан бу купшы чәчкә бер-ике көн үтүгә шәлперәеп төшәчәк, ә миңа бу тыйнак кына утырган хризантемалар, лилияләр, күзне иркәләп, ай буе чәчәктә сакланыр.* А.Әхмәтгалиева

**ЧӘЧКӘЛӘНҮ** *ф. к.* **чәчәкләнү**. *Шул чәчәккә охшап елмайсаң, Шул чәчәкләр белән чәчкәләнеп Үсканеңне сөеп мин язсам, Кайберәүләр тиргәп сукраналар.* К.Гыйззәтов

**ЧӘЧКЕН** *и.* Үсенте итеп утыртылганнан аермалы буларак, орлыктан үстерелгән яки үскән үсемлек. *Орлыклардан чәчкен үстерү өчен, махсус урман питомниклары булдырылган.* Минзәлә газетасы. *Майның башында салкын рассадникларга, чәчкен (рассада) алу өчен, кәбестәнең уртача өлгерешле сортларын (Слава, Осенняя Грибовская һ.б.) чәчәләр.* Саба таңнары

**ЧӘЧКЕРЧЕ** *и. иск. к.* **чәчтараш**

**ЧӘЧКЕЧ** *и.* Орлык чәчү һәм туфрак ашлау өчен кулланыла торган авыл хуҗалыгы машинасы. *Алдагы чәчкеч артына баскан Газинур, корыч сотникларга алтын бодай агуын күзәтеп, бөртекләрне куллары белән тигезли.* Г.Әпсәләмов. *Чәчкеч, урак машиналарын көйләргә Юкәле авылына да чакырдылар.* Р.Кәрами

**ЧӘЧЛЕ** *с.* 1) Билгеле сыйфатка ия чәче булган; гомумән чәче булган. *Янәшәсеннән култыклашып үтеп киткән карт белән карчыкны да, әнисен җитәкләгән бөдрә чәчле сабыйны да күңел күзе белән күрмичә, җансыз курчак шикелле атлавын белә.* А.Әхмәтгалиева. *Аларны үзенең ишеге төбендә ак чәчле, акыллы кара күзле, гади киемнән сөйкемле әби каршылады.* А.Нәҗми

2) Нindидер максат өчен чәч кулланылган, чәчтән файдаланган. *Чәчле гигрометр һаваның дымлылыгын билгеләүдә артык төгәллек кирәк булмаган очракларда кулланыла.* Физика

**ЧӘЧМӘ** *с.* 1) Шигъри булмаган, проза белән язылган. *Салих абыйның чәчмә әсәрләрен күңел биреп һәм ошатып укуым шушы романнан башланган иде.* М.Хуҗин

2) *махс.* Зур пространствога тарала торган, бер урынга төбәлмәгән, юнәлдерелмәгән (яктылык тур.). *Фабрикаларда һәм заводларда күбесенчә чәчмә яктылык бирә торган яктырткычлар кулланыла.* Анатомия

**ЧӘЧПИ** *и. диал. к.* **чәчби**. *Рәшидәнең әкрен кыймылдаганына үч алуы булгандыр дип уйлап, ул чәчпине әрләп алырга булды.* Безнең гәҗит

**ЧӘЧРӘВЕК** *и.* Кинәт бәргәндә, басканда һ.б.ш. очракларда читкә атылып киткән сыеклык тамчылары

**ЧӘЧРӘМӘ** *и. диал. к.* **чәчрәвек**. *Якыннан, томан һәм су чәчрәмәсе эченнән, йөгереп, ухылдап, бер кеше узып китте.* Г.Бәширов

**ЧӘЧРӘП** *рәв. сөйл.* 1) Көч белән, бик кинәт; атылып. *Бабайның озын күлмәгендә кесә эзләп маташканын күргән Мәдинә чәчрәп сикереп торды.* А.Әхмәтгалиева

2) күч. Кызуланып, ачуланып, усалланып

**ЧӘЧРӘТҮ** *ф.* 1) Көч белән читкә атылдыру, сиптерү (сыеклыкны). *Барабаннар бертуктамый шаулап, су чәчрәтеп әйләнәләр.* А.Алиш. *Ул юыну бүлмәсенә битен генә юарга дип кергән җиреннән җылы су агымына үзе дә кереп басты --- суны тәненә чәчрәтте.* А.Нәҗми

2) Атып-атып җибәрү, тарату, очырту. *Утын чаткы чәчрәтеп ята*

3) *күч.* Төрле якка сибү, чәчү. *Бәпкә үләннәре өстендәге энҗе бөртекләре шикелле нур чәчрәтеп уйнаган тамчыларның яктылыгы, яңгыр исе белән аралашып, өй эченә иңгәндәй булды...* Ә.Еники. *Теге биюче кызны әйтегез*

*сез, бөтерчек төсле әйләнеп китә, ничек егылмый, сәхнәдә очкын чәчрәтә бит, ут уйната.* А.Гыйләҗев. *Рәиснең күзләре ут чәчрәтеп яна иде.* А.Фәләх

4) Бәреп, сугып очырту

5) *күч. гади с.* Үтерү, дөмектерү. *[Солдатларның] кайберәүләре эчләреннән: «Берсен чәчрәткәннәр икән. Бик яхшы. Безне шуның өчен кайгыра дип уйлаганнардыр, ләкин ялгышалар».* М. Гафури

**ЧӘЧРӘ́Ү** *ф.* 1) Көч белән читкә атылу, сибелү (сыеклык тур.). *Биредәге таш тишекләреннән кайнар тамчылар чәчри, су буенда төрле төстәге таштан матур бизәкле түгәрәк мәйданчыклар ясалган иде.* М.Маликова. *Сөт тамчылары битенә чәчри...* Н.Гыйматдинова

2) Төрле якка барып төшү, чәчелеп барып төшү; төрле якка атылып китү (вак кисәкчекләр тур.). *Ат тоягыннан, тәгәрмәчләрдән як-якка җиңелчә балчык кисәкләре чәчрәп калды.* Н.Фәттах

3) *күч.* Кечкенә генә яки тар тишек аша үтү, үтеп чәчелү (яктылык тур.). *Солдатның башына күсәк белән суккандай булдылар, күзләреннән утлар чәчрәде.* Г.Әпсәләмов. *Ул егылуга, Вилдан җил кебек очып килеп җитә, тимераяклары астыннан боз кыйпылчыклары чәчрәтеп, кырт борыла, Мәрьямнең култык асларыннан күтәреп аягына бастыра да тагын шуып китә.* М.Маликова

4) *күч. гади с.* Үлү, юкка чыгу

◊ **Чәчрәп китим** *гади с.* Берәр сүзнең, фикернең дөреслегенә башкаларны ышандыру өчен ант итеп әйтелә. *[Җиһанша:] Исән генә котылыйм. Мин сине кызыл үгездән сөздерәм, чәчрәп китим, сөздерәм!..* Т.Гыйззәт. *Ә дөресен генә әйткәндә, туташ сезнең баруыгызны абыйсына караганда да ныграк тели, чәчрәп китим менә!* Ә.Еники. **Чәчрәп китсен** *гади с.* Бик нык ачулануны, үпкәләүне һ.б.ш. белдерә. *Мәликә апаның зарлануын үз колакларым белән ишеттем, дип әйтә алмады, күңеле йомшарып, тамагына утлы төер бөялде. Зарланды бит, чәчрәп китсен менә.* Н.Гыйматдинова. *Бердәнбер кызы чәчрәп китсен, тик аның карьерасы күтәрелсен!* Н.Гаетбай. **Чәчрәп тору** 1) Бик уңган, бик җитез һәм өлгер булу. *Алия ул чәчрәп тора, Ут кебек дөрләп тора.* Р.Миңнуллин; 2) Усал телле, бик нык әреплэшергә яратучан булу. «*Нинди эшең бар, апа?» – дип чәчрәп тора.* Р.Бәшәр; 3) Күзгә бәрелеп тору, аңлашылу. *Бу Кәрим Гайфи үзе яшьтән үк зирәклеге чәчрәп торган бала иде.* Г.Ибраһимов. **Чәчрәп чыгу** 1) Нәрсәгә дә булса кискен каршы чыгу, каршы төшү. *Бу юлы исә Җир йөзендә көннән-көн арта, ишәя барган гаделсезлеккә каршы үзенең кискен сүзен әйтмичә калырга түземлеге калмаганга, шулай чәчрәп чыккандыр.* А.Хәсәнов; 2) Берәр нәрсәгә карата бик тиз реакция ясау. *– Бирмиме?! – дип чәчрәп чыкты Әхмәт.* А.Гыймадиев

**Чәчрәп бетү** Бөтен тирә-якка күп булып чәчрәү. *Баланың күлмәгенә, түшеннән итәгенә кадәр, хәтта аякларына да шәмәхә кара чәчрәп беткән иде.* Д.Каюмова. *Һәркайсының үз көч-куәте бар, берсе әнә Биюшнең йон тубыдай атылып сикерә, икенчесе такта буйлап шуып кына китә, өченчесе тирәюньгә чәчрәп бетә.* М.Хуҗин

**Чәчрәп китү** Кинәт чәчрәү. *Ап-ак тамчылар, чиләктән чәчрәп китеп, ялгыш аның каракучкыл (кояш астында күп эшләгәннән ул) йөзенә, тамырлары калкып чыккан кулларына килеп куналар.* Г.Гыйльманов

**Чәчрәп тору** Гел чәчрәү

**Чәчри башлау** Чәчрәргә тотыну. *Эчтә, зәңгәрсу яктылык сирпеп, ниндидер очкыннар чәчри башлады.* Ф.Хуҗин. *Шундый ук эш башка җирдә булып торганда, нигә «электр кыры» куертып, кайчан очкыннар чәчри башлаганны көтеп йөрергә ди әле...* З.Мифтахов

**ЧӘЧТАМЫР** *и. бот.* Үсемлек тамырының бик нечкә үсентесе; *русчасы:* **корневой волосок**

**ЧӘЧТАРАШ** *и.* Чәч алу, кисү, буяу, тарау һ.б.ш. белгече, парикмахер. *Минә көне килде, сугыш чыкты, сугыш күпләрне тигезләде: --- малайшалайның башын ялтыратып куючы чәчтараш Сибгать абзый да, абруйлы шадра тимерче Нурулла да, мичкә төпләүче, дуга бөгүче Колга Сабир да бер көндә солдат булдылар.* А.Гыйләҗев. *Әмма чәчтараш, куркуын эченә йотып, бер сүз әйтми, тып-тын гына утыра икән.* Р.Вәлиев

**ЧӘЧТАРАШЛЫК** *и.* 1) Чәчтараш һөнәре, чәчтараш хезмәте. *Полицейскийлар киткәндә, үзләренә ияртеп, әлеге чәчтарашлык белән хыялланып йөргән Сиражетдин Билуковны да алып киттеләр.* Ә.Фәйзи

2) Чәч кисү, буяу, тарау осталыгы, һөнәре. *Чәчтарашлык сәнгате*

**ЧӘЧТАРАШХАНӘ** *и.* Чәч алу, буяу, тарау, шулай ук сакал-мыек китәрү кебек хезмәтләр күрсәтә торган оешма. *Бауман урамындагы Матбугат йорты белән рәттән генә чәчтарашханә бар иде.* Г.Гомәр. *Мәрьям үз йортлары астына урнашкан чәчтарашханә янында капылт кына туктап калды.* З.Хөснияр

**ЧӘЧТАРАШХАНӘЧЕ** *и. ялг. к.* **чәчтараш**. *Лилия чәчтарашханәче булып эшкә керде*

**ЧӘЧТӘҢКӘ** *и. этн.* Чәчне бизәү өчен, чулпыга охшатып, тасмага яки бауга тезелгән көмеш яки башка төрле металлдан ясалган тәңкә. *Хәситә дә анда, чәчтәңкә дә, энҗеләре исән калфак та...* Р.Фәйзуллин. *Зыңла, алтын чәчтәңкә!* Р.Батулла

**ЧӘЧҮ** I *ф.* 1) Әзерләнгән туфракка орлыклар салу, сибү. *Каравыл өе алдын чыбык читән белән үреп алып тырлау ясады, мул итеп укроп чәчте, кыяркәбестә утыртты, шешә алып килсәң, кабарга дигәнен үрелеп кенә ала...* А.Гыйләҗев. *Язын сабан сөрде, муенына тубал асып, сөргән җиргә ашлык чәчте, печән өстендә печән чапты, кибән куйды, урак өстендә ашлык сукты, эскерт өйде, кышын балык тоту бригадасында катып-калчаеп боз тишәте, елым тартты.* Д.Каюмова

2) Төрле җиргә төшерү, ташлау, сибү. *Извиль акчаларны идәнгә чәчә.* Х.Ибраһим

3) Чәчрәтү. *Кавынбаш, Сәет ягына борылып, яңадан төкерек чәчә башлады.* М.Хәсәнов

4) Җирне ашлык һ.б.ш. үстерү өчен файдалану. *Без, ди торган иде, Керенский егылганны да көтмәдек, күрше боярларның җирләрен җәйдән үк сөреп чәчтек, йортларын тартып алдык...* Г.Ибраһимов. *Кәнсәләр эше тавык та чүпләп бетермәстәй күп булгач, сабанны әти берүзе сөреп чәчте, тырмага Шамил йөрде.* Ш.Маннур

5) Төрле якка тарату, сибү (нур, яктылык һ.б. тур.). *Мин инде абаганың, кечкенә йолдыз төсле, сыек зәңгәр нур чәчеп, бөтен урманны балкытуын күз алдыма ук китердем.* Г.Бәширов

6) *махс.* Тарату, төрле якка җибәрү, җәелдерү. *Батынкы линза, үзе аша үтә торган нурларны сындырып, як-якка чәчеп җибәрә. Андый линза чәчә торган линза дип атала.* Физика

7) Тарату, яңгырату (тавыш тур.). *Моң чәчеп сайрый былбыллар.* Ф.Дәүләтбаев

8) *күч.* Төрле җирдә барлыкка китерү, тарату. *Сугыш чәчкән матәм кайгылары Күпме Ана йөрәген өтәр.* Ә.Синугыл

9) *күч.* Ниндидер, үзенә бер төрле хис белдереп карау (күзләр турында). *Кара, бүтән чакта мыштым гына йөргән кешене танымассың да: күзләр очкын чәчә, кашлар җәядәй язылган, мыек көлеп, бөтерелеп тора.* Т.Гарипова

10) *күч.* Кешеләр арасына тарату, массаларга җиткерү. *Чүгүчәктә татарлар сәнгать, мәгърифәт чәчү белән генә чикләнмәгән, шәһәр, дәүләт тормышына да шактый өлеш керткән.* Р.Гыйлемханов

11) *күч.* Сөйләргә ярамаган хәбәр, сер һ.б.ш.ны күпләргә билгеле итү, тарату (хәбәрне, серне һ.б.ш.). *Бу көннән соң Сәримә Гөлчирә турында авылда уңлы-суллы гайбәт чәчте.* Д.Каюмова. *Кыз дусты ягына авышып беткән, хәтта авылда, Гыйләҗетдин кызын театрдан куганнар, базарда чүпрәк сата, дип гайбәт чәчәрләр инде, дигән курку да югалган иде.* Н.Гыйматдинова // Махсус рәвештә сөйләп йөрү

12) *сөйл.* Туктаусыз сөйләү. *Яшьрәк байлар көлешә, үткерлекләр, тапкырлыклар чәчә иделәр.* Ш.Камал

13) *күч. сөйл.* Пулемёт, автомат һ.б.ш.дан туктаусыз ату, атып тору. *Дошманны чигендерер өчен бүтән берниндичара да калмагач, Матросов туктаусыз ут чәчеп торган амбразурага таба шуыша башлый.* В.Нуруллин

14) Маймыч яралсын өчен, организмнан уылдык бүлеп чыгару (балыклар тур.). *Тагы да тотар әле, балыкларның, өерелеп, үргә таба, уылдык чәчәргә менгән вакыты, мондый чакта әллә күпме тотарга була.* З.Мурсиев. *Ләкин Газиз карт та, Фатыйма карчык та, хәтта Зәйтүнә кортка да балыкларның ничек парлануын, ничек кавышуын, кайчан уылдык чәчеп, ничек гаилә коруын белмиләр иде.* Г.Гыйльманов

**Чәчә башлау** Чәчәргә тотыну. *Шунда ук, тояклары белән тибенеп, тирәякка алтын-көмеш чәчә башлаган.* Г.Гыйльманов

**Чәчә тору** Әледән-әле чәчү; берәр эш-гамәлдән алда чәчү; фактта чәчкән булу. *Тагын да соңрак, май ахырларында, яңа урамдагы Әлфия апа бакчасын, бөтнек чәчә торып, мәче борчагы басып алган?!* З.Хөснияр

**Чәчеп алу** Тиз генә чәчү. *Тәрәзә өстенә оялаган тиктормас чыпчыкларга тикле, тынып, табигатьнең гайрәт чәчеп алуын көтте...* А.Тимергалин

**Чәчеп бару** Эзлекле рәвештә чәчү. *Әти алдан чәчеп бара, мин аның артыннан тырмалап барам.* Г.Бәширов. *Зәбирнең җаны аны эзләп менсә, адашмасын, таба алсын өчен, Зөбәрҗәт үз каурыйларын, күз яшьләре белән сөртәсөртә, шул рәвешчә чәчеп барган икән.* В.Имамов

**Чәчеп бетерү** Тулысынча, ахырына кадәр чәчү; барысын да чәчү. *Мин авылга кайтып төшкәндә, солы, борайны чәчеп бетергәннәр, тары, карабодайга яңа чыкканнар гына иде әле.* Г.Ибраһимов. *Башта янчыгыннан махоркасын ала алмый җәфаланды, яртысын җиргә чәчеп бетерде, төргәч, ялап-ялап ябыштырып маташты.* З.Кадыйрова

**Чәчеп җибәрү** Кинәт яки ялгыш чәчү. *Ул бер уч шакмакны чәчеп җибәреп, берсен-берсенә чиртеп тидерә дә аларны яңадан корышып беткән кулына җыя бара.* М.Галәү. *Пычкының чылбыры бик каты сызгырып, тешләре арасына кысылып калган агач чүбен чәчеп җибәрде һәм җиңел генә агачның кутырлы кәүсәсенә барып та керде.* Д.Каюмова

**Чәчеп йөрү** Анда-монда таратып чәчү. *Кайда яшәгәнегезне чәчеп йөрмисез.* А.Гыйләҗев. *Әгәр сезнең халыкны туйдыру өчен иген чәчеп йөрсәк, тегермәннәр төзесәк, арба, камыт, сабын ясап бирсәк, киндер тукысак, әлбәттә, падишаһ этләренә сез теш-тырнагыгыз белән каршы чыгар идегез.* В.Имамов

**Чәчеп кую** Алдан ук чәчү. *Кипсен дип чәчеп куйган шырпы бөртекләренең юк булуын белгәч кенә моның аю эше түгеллеген сизеп алдым.* К.Җәмит. *Алтын-көмеш чәчеп куйганнар ди анда сиңа!* Р.Низамиев

**Чәчеп тору** Бертуктаусыз чәчү; хәзер, әле чәчү. *Хәйләкәр, усал, битараф карашларны күреп, ирексездән нур чәчеп торучы, ихлас күзләр эзләдем.* А.Мансуров. *Айсылу исә – кәтүк, үзе тиктормас, чегән баласы кебек капкара, ә күзләре зәңгәр, ут чәчеп торалар.* З.Кадыйрова

**Чәчеп чыгу** Булган берсен берәмберәм чәчү; башыннан ахырына кадәр чәчү. *– Җиремне тырнагым белән тырмап булса да барыбер сөреп чыгам! – дип, ашыга-ашыга, җирләрен чәчеп чыктылар.* М.Галәү

**ЧӘЧҮ** II *и.* 1) Басуда башкарыла торган эшнең бер төре буларак, әзерләнгән туфракка орлыклар сибү, салу эше. *Язгы чәчү барган көннәрдә колхоз, кысыр сыер, я булмаса, кышлау үгез суеп, ир-ат механизаторларны җыеп, шәп кенә мәҗлес үткәреп ала торган иде.* А.Гыйләҗев

2) Иген чәчү вакыты, шул эш чоры. *Шулай итеп, мин язгы чәчү беткәнче тырмада йөрдем.* В.Нуруллин. *Шундый оста итеп сөйли ул урып җыю, ашлык эшкәртү, орлык салу, хәтта көзге чәчү турында.* Т.Нәҗмиев

**ЧӘЧҮ ӘЙЛӘНЕШЕ** *и. а.х.* Берничә ел эчендә бер үк мәйданда авыл хуҗалыгы культураларын чәчүне эзлекле рәвештә чиратлаштыру алымы. *Туфракның нинди икәнлеге беркайда да язып беркетелмәгән, чәчү әйләнешенең планнары юк, кырлар ашланмаган, барлы-юклы тиресне шунда фермалар, кардалар янындагы чокырларга аударып килгәннәр.* А.Гыйләҗев. *Ул вакытта игенчелектә өч басулы чәчү әйләнеше өстенлек итте, һәм тимер сабан башлыча алпавыт хуҗалыкларында гына кулланылды.* Р.Зарипов

**ЧӘЧҮЛЕК** *и.* **1.** 1) Иген чәчелгән җир, чәчелә торган мәйдан. *Аның каравы, хуҗалыктагы башка әйберләр, чәчүлек һәм каралты-кура бик очсыздан китте.* М.Галәү

2) Чәчкәннән соң үсеп чыккан иген. *Җәзалап йөрүчеләр фермаларны яндыралар, терлекләрне һәм чәчүлекләрне юк итәләр.* Яңа тарих

3) Чәчәргә билгеләнгән ашлык; орлык. *Кояш торган саен ныграк чыбыркылый, бүген-иртәгә язгы чәчүгә төшәсе, хуҗалыкта булган бөтен сукатырмаларны, чәчүлек орлыкны барлап куясы бар.* В.Имамов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Иген чәчелгән, иген чәчелә торган. *Чәчүлек җирләрне күпме харап итәләр.* А.Гыйләҗев. *Бар җире мең дә ике йөз гектар булып, шуның чәчүлек мәйданы нибары җиде йөз дә җитмеш өч гектар гына иде.* В.Нуруллин

2) Чәчәргә билгеләнгән, орлыкка дип билгеләнгән. *Шуләнгер бакчалары ак чәчәккә күмелгән, каз бәпкәләре чирәмгә баскан, көтүләр чыккан, чәчүлек бәрәңгеләр үргән иде.* К.Кәримов

**ЧӘЧҮ МАШИНАСЫ** *и. к.* **чәчкеч**. *Ватылган чәчү машинасын, теше сынган тырманы алачыкка алып киләләр, ә анда нәселле эт башы чаклы йозак эленеп тора.* Т.Галиуллин

**ЧӘЧҮРӘ** *и. жарг.* Сөяркә. *Кемдер әле: «Менә шушы инде Тимернең чәчүрәсе», – дип күрсәткән дә иде.* М.Хәсәнов

**ЧӘЧҮРГЕЧ** I *и.* Чәчкә кушып үрелә торган тасма, бау. *Чәчүргеч башындагы көмеш тәңкәләре атлаган саен сел-*

*кенгәләп, чылтыр-чылтыр тавыш биреп баралар, аның кечкенә генә колакларында зур көмеш алкалар селкенгәли.* Н.Яһудин. *Җилдә җилфердәп калды тик Чәчүргеч тасмаларың.* Н.Гамбәр

**ЧӘЧҮРГЕЧ** II *и. диал.* Кайбер хайваннарның муенында була торган бик тыгыз һәм каты тукыма, сеңер

**ЧӘЧҮ́ ЧӘЧҮ** *ф.* Чәчү II (*1 мәгъ.*) эшендә булу, чәчүдә эшләү. *Язын чәчү чәчкәндә дә, игеннәр яшел чакта да, өлгергәч тә, аларны урганда да, ургач та, сөргәндә дә, кыш көне дә матур басулар.* Ф.Садриев. *Язын күмәкләшеп чәчү чәчәбез дә көз белән бергә җыячакбыз, уртак бүләчәкбез...* В.Имамов

**ЧӘЧҮЧЕ** *и.* Иген чәчү эшен башкаручы кеше. *Начар чәчүченең игене дә начар була.* Мәкаль. *Бу елны безнең колхоздан иң яхшы чәчүче булып Габдерәкыйп саналганлыктан, минем белән ул да барды.* Ф.Галиев

**ЧӘШКЕ** I *и.* **1.** *зоол.* 1) Сусарчалар семьялыгыннан кыйммәтле мех бирә торган зур булмаган җәнлек; *русчасы:* **норка**

2) Шул җәнлекнең мехы

**2.** *с. мәгъ.* Шул җәнлекнең мехыннан тегелгән. *Чәшке бүрек модада бит хәзер.* М.Маликова. *Иблис карга мәтәлде, чәшке бүреге читкә тәгәрәп китте.* З.Мәхмүди

**ЧӘШКЕ** II *и. рус* Чынаяк, чынаяк чокыры. *Улы Касыйм, өйгә йөгереп кереп, чәшке алып чыга.* А.Алиш. *Назыйм абый, кулына чәшке белән чәй тоткан килеш, бүлмә буйлап йөреп китте.* М.Вәлиев

**ЧЕБЕН** *и. зоол.* Икеканатлылар отрядыннан кеше яши торган урыннарда таралган бөҗәк. --- *үрмәкүч пәрәвезен сузган, чебенне шунда эләктереп алган һәм канын эчәргә тотынган.* А.Алиш. *Чебен безләгәннән филләр өркәме дә, чебен кырылганга алар кайгырамы?* В.Имамов

◊ **Чебен балга ябышкан кебек** Бик күп кеше берәр нәрсә белән нык кызыксыну турында. *Минә гармунчының базары төшми. Кызлар аңа чебен балга ябышкан кебек ябышалар.* Г.Әпсәләмов. **Чебен булып күзгә керү** Тартынмыйча әрсезләнү. *Чөнки Күкчә кем икәнен оныта, артык масаеп китеп, чебен булып күзгә керә, авыр тузан булып тын юлына утыра башлый.* А.Хәсәнов. **Чебенгә дә тимәс** Кызганучан; барлык җан иясенә җәлләп карый торган кеше турында. **Чебенгә күсәк күтәрү** *к.* **чебенгә чукмар күтәрү**. **Чебенгә сука җигү** Берәүгә булдыра алмаслык эш тагу. *Конкага җигелгән атлар җан авырттырырлык кызганыч вә теге сакаллы сабыйлар тарафыннан мәзлум тоелалар иде. Бу бөтенләй чебенгә сука җигү булып күренә иде.* Г.Тукай. **Чебенгә чукмар күтәрү** Кечкенә генә мәсьәләне хәл итәргә зур көч кую. --- *имтихан алучы Корбан Тимергалиевич Вәлитов, нидәндер шикләнеп, безне иң алгы рәткә күчереп утыртты. Бу аның тарафыннан чебенгә чукмар күтәрү иде инде.* Б.Камалов. *Холкы сабыр, әтрафлы, беркайчан да йөгереп, кабаланып китмәс, чебенгә чукмар күтәрмәс, җил-буран уйнатмыйча гына, тирә-як урманга тулы хуҗа булып йөрер.* Т.Галиуллин. **Чебен дә кундырмау** Бик нык саклау; бөтен шартларны булдыру. *Мөстәкыйм әфәндегә без чебен дә кундырмаска тиешбез.* Д.Салихов. **Чебен дә үтә алмау** Бик нык саклану. *Сакчылар, ишекне киң ачып, боларны эчкә уздырдылар. – Хуп, мулла абзый, чебен дә үтә алмас! – диделәр.* Г.Бәширов. *Ул бит бик зур кеше! Аның янына чебен дә үтеп керә алмый!* М.Вәлиев. **Чебен дә үтәрлек түгел** Тыгыз һәм биек итеп тотылган; бик нык сакланган (корылма). **Чебен дә үтермәс** Бик юаш, кызганучан. **Чебен дә рәнҗетмәс** *к.* **чебен дә үтермәс**. **Чебен кебек үрчү** Бик нык ишәю, чамасыз арту. *Чөнки фани дөньядан оҗмах эзләүче, оҗмах яратучы[лар] чебен кебек үрчегән.* З.Мәхмүди. **Чебен кирелеге** Урынсыз үҗәтлек. **Чебеннән фил ясау** Берәр мәсьәләне катлауландыру, бик күпертеп күрсәтү. *Безнең Гордеев кебек чебеннән фил ясаучы кешеләр бетмәгән әле дөньяда.* Г.Әпсәләмов. *– Апа, чебеннән фил ясама, зинһар, – диде Вәсилә.* Н.Гыйматдинова. **Чебенне фил итү** *к.* **чебеннән фил ясау**. *Чебенне фил итеп, төтенне тау итеп, юк нәрсәләрне күпертәләр, кабарталар.* Г.Исхакый. **Чебен очканны да ишетерлек** Тирән тынлык урнашу турында. *Мәдрәсәләрдә китап киштәсе, Сак белән Сокның бәетен ишетәсе... – дип башлап җибәрүеңә, өйдә чебен очканны ишетерлек тынлык урнаша.* Г.Бәширов. *Шулай итеп, актлар залында чебен очканны да ишетелерлек тынлык хасил булды.* А.Гыймадиев. **Чебен сыткан кебек** *к.* **чебен урынына да күрмәү**. *Мин синең кебекләрне чебеннәрне сыткан кебек сыттым һәм ары таба да сытачакмын.* И.Хуҗин. **Чебен таеп егылырдай** Бик шома, чиста. *Урынбасарның чебен таеп егылырдай шома башында бөрчек-бөрчек тир бәреп чыкты.* З.Мәхмүди. **Чебен тешләгән кебек** Көчле авырту сизмәү турында. *Минем ише коры сөяккә калган, чыкмаган җаны гына булган кешенең сугуы андый әзмәвердәй фашиска нәрсә инде ул? Чебен тешләгән шикелле дә булмагандыр.* В.Нуруллин. **Чебен тимәс чер итәр** Тиз үпкәләүчән кеше яки иркә, еларга гына торган бала турында. *Доктордан да бигрәк, шушы чибәр шәфкать туташы алдында аның чебен тимәс чер итәр бер мәмкә булып күренәсе килмәде.* Н.Әхмәдиев. *Шәһәр кызлары чебен тимәс чер итәр була бит ул...* А.Әхмәтгалиева. **Чебен тоту** Эшсез яту. **Чебен урынына да күрмәү** Кызганмау. *Алар безне чебен урынына да күрмәячәк, диючеләр күбрәк ---.* А.Тимергалин. *Холкым бик начар, чебен урынына да күрмәм.* З.Мәхмүди. **Чебен урынына кыру** Күпләп юк итү, үтерү. *– Ә бездә кеше кадәр кешене чебен урынына кыралар, – диде Айваз, исе китеп.* З.Мәхмүди. **Чебен урынына үрчү** *к.* **чебен кебек үрчү**. *Чебен урынына үрчеделәр имансыз адәмнәр ---.* К.Кара. **Чебен урынына үтерү** *к.* **чебен урынына кыру**. *Кешенең бер дә кадере калмады. Чебен урынына то̇талар да үтерәләр.* Г.Бәширов

**ЧЕБЕ́Н ГӨМБӘСЕ** *и.* Аманитачалар семьялыгыннан кызыл эшләпәсендә ак таплары булган, төнәтмәсе чебен үтерү өчен файдаланылган агулы гөмбә. *Агуланам, Хәерлебанат аркасында чебен гөмбәсе ашап харап булды асыл җегет Гыйльметдин, дисеннәр.* Р.Батулла. *Чебен гөмбәсе җыеп йөрми микән дип, урманны айкап чыктылар – юк Мөдәррис.* Л.Лерон

**ЧЕБЕНҖАН** *и.* Куркак кеше. *Тормышта, әдәби әсәрләрдә кемнәрнеңдер кемнәрнедер чебенҗан дип әрләүхурлауларын еш очратырга туры килә.* Х.Мәхмүтов

**ЧЕБЕ́Н-КИГӘВЕН** *җый. и. к.* **чебен-черки**. *Кырдагы хайваннар, һаваның кыздыруына һәм исәпсезсансыз чебен-кигәвенгә түзә алмыйча, тибенә-тибенә, койрыклары белән ярсып селтәнә-селтәнә, инеш буйларына, өянкеләр күләгәсенә чабыштылар.* Г.Бәширов. *Шуннан соң ул туктаусыз авызлык тимерләрен чылтыратып, башын чайкап, койрыгын селтәп, чебен-*

*кигәвен куып торган кара бияне иплән кенә, җайлап кына капка ягына борды.* Н.Фәттах

**ЧЕБЕ́Н КОРТЫ** *и.* Бозылган ризыкта барлыкка килә торган һәм балык тотканда кулланыла торган корт; *русчасы:* **опарыш**. *Бу кызыл суалчаннарга, бу ак чебен кортына – без тиешбез ким дигәндә ярты чиләк тотарга!* Р.Фәйзуллин

**ЧЕБЕНКОШ** *и. зоол.* Колибри

**ЧЕБЕ́Н КУНАЧАСЫ** *и. бот.* Кузаклылар семьялыгыннан ак яки сары чәчәкле кумарин исле үсемлек. *Ул да елның елында чираттагы ялын чәчәкләргә ишелеп бал төшәр алдыннан, урман аланына, карабодай басуына, эспарцет, чебен куначасы чәчелгән болыннар уртасына кортлары белән чыгып утырыр көннәр җиткәч ала.* А.Хәсәнов

**ЧЕБЕ́Н КУНГЫСЫ** *и. к.* **чебен куначасы**

**ЧЕБЕНКУНМАС** *и. бот.* Иренчәчәклеләр семьялыгыннан шәмәхә чәчәкле хуш исле үлән үсемлек; шалфей. *Чебенкунмас гөл (шалфей) да бик күп бездә.* Безнең гәҗит

**ЧЕБЕНЛӘ́Ү** *ф.* 1) Эссе көннәрдә башны һәм койрыкны селкеп, чебенчеркине куу (хайваннар тур.). *Таш булып каткан пар басуын сөргәндә, сабан токасы сине – сабаннан аз гына калкурак үсмер малайны чөеп-чөеп ыргыта, кигәвен вакытында атың, кая барып бәреләсен белмичә, үрле-кырлы сикерә, чебенли торгач, сөйрәп читкә алып чаба.* Г.Бәширов

2) Азыкта, үсемлекләрдә һ.б.ш. нәрсәләрдә күпләп чебеннәр пәйда булу. *Агуланудан саклану өчен, түбәндәге кагыйдәләрне үтәргә онытмагыз: гөмбә аз гына шикләндерсә дә алмагыз; аларны юл буйларыннан җыймагыз; искергән, чебенләгәннәрен өзмәгез дә; җыйган көнне үк эшкәртегез; очраклы кешеләрдән сатып алмагыз.* Маяк

3) *күч.* Ыгы-зыгы килү, тыз-быз йөрү. *Бабай йөри шыбынлап, әби йөри чебенләп.* Әйтем. *Ник амин итмәдең, ник чебенләдең, дип битәрләргә режиссёрның хакы бармы?* Г.Гобәй

**Чебенләп алу** Бераз чебенләү. *Әгәр өйгә кайткач, бераз [ир] чебенләп ала икән, чәпчемә: ир – баш, хатын – муен!* Т.Әйди

**Чебенләп тору** Әле, хәзер чебенләү.

**Чебенләп утыру** *сөйл. к.* **чебенләп тору**. *Юл буе агач төпләренә куеп калдырылган чебенләп утырган пакетлар, ташланган төзелеш материаллары, буш шешәләр.* Шәһри Казан

**ЧЕБЕНЛЕ** I *с.* Чебен очып торган; чебен белән тулган. *Шәһәрнең тузанлы, чебенле базары җиләк-җимеш белән тулды.* И.Гази

**ЧЕБЕНЛЕ** II *и.* Кыска гына казык башына куелган чүрәкәйне (чебенне) таяк белән бәреп төшерүдән гыйбарәт балалар уены. *Бергә күршеләр булып үскәннәр. Шаралы, чебенле уйнап, Эстәрле суына кәрҗин белән ташбаш, маймыч, этем балыклары тотканнар.* З.Зәйнуллин

**ЧЕБЕ́НТОТКЫЧ** *и. зоол. к.* **чебенче**

**ЧЕБЕ́Н ҮЛӘНЕ** *и. бот.* Спаржачалар семьялыгыннан коры климатлы төбәкләрдә үсә торган вак яфраклы үсемлек; *русчасы:* **спаржа**

**ЧЕБЕ́НҮТЕРГЕЧ** *и. к.* **чапалак** (*2 мәгъ.*). *Рәүф, китереп бир миңа чебенүтергечне.* Л.Лерон

**ЧЕБЕНЧЕ** *и. зоол.* Чебенче кошлар семьялыгыннан бөҗәкләр белән туена торган яссырак киң томшыклы, кыска аяклы кечкенә кош; *русчасы:* **мухоловка**. *Чебенче кош сайравы дәртләндерә, кәефне күтәрә.* Сабантуй

**ЧЕБЕНЧЕЛ** *и. бот.* Чыклылар семьялыгыннан үзенчәлекле яфраклары белән үзенә кунган бөҗәкләрне эләктереп туена торган үсемлек; *русчасы:* **мухоловка**. *Ә менә чебенчел үзенең яфрак-казналыклары ярдәмендә кечкенә баканы да эләктерә ала.* Биология

**ЧЕБЕ́Н-ЧЕРКИ** *җый. и.* Чебенгә охшаш һәртөрле кан эчүче, тешләүче бөҗәкләр, черкиләр һ.б.ш. *Ачыксалар Карлыгачның балалары, Чебен-черки тотып кайта аналары.* Г.Тукай. *Күләгәгә бәйләнгән атлар, арба-кырандасларга, читән буйларына анда-монда салыштыргаланган яшел печән күбәләреннән үлән берәмтекләгәндә, вакыт-вакыт, койрыклары белән чәнчеп-чәнчеп, чебенчеркиләрне кугалаштырып ала.* А.Хәлим

**ЧЕБЕ́Н ЧЫПЧЫГЫ** *и. к.* **чебенче**

**ЧЕБЕРДӘ́Ү** *ф. диал.* Вак кына тамгалап, нәзек кенә агым белән агу; шыбырдау. *Аның гимнастёрка һәм чалбарларыннан чебердәп су ага ---.* Ш.Маннур

**ЧЕБЕ́Ш** *и.* 1) *к.* **чеби** (*1 мәгъ.*). *Чебешләренә куркыныч янаганда, хәтта чуар тавык та, үз-үзен белешмичә, тилгән-карчыгга, хәтта бөркет өстенә ташлана.* А.Хәсәнов

2) *к.* **чеби** (*2 мәгъ.*). *Журналларга язылдым. Көн саен чебеш суям. Минем дә кешечә картаясым килә.* А.Гыйләҗев

3) *күч.* Кечкенә кеше; ябык, көчсез кеше. *Корсакларыбызга шапылдатып суга-суга, һәммәбезне бер карап әйләнде дә безнең ише кечерәкләрне: «Батмый бәләкәй!» – Я булмаса: «Кечкенә – чебеш кенә!..» – ди-ди, муеннарыбызга чиерткәләп, читкә куып бетерде.* Г.Бәширов. *Ул чибәрлек, ул буй, көч, аның янында мин чебеш кенә ---.* К.Кара

4) **чебешем, чебешкәем** *тарт. форм.* Иркәләп, яратып эндәшү сүзе. *--- җырларны тыңлаганда, кырыс солдаткаларның күзләренә ихтыярсыз яшь килә, кайберләре: «И Муса балакаем! Чебешкәем!» – дип кочып үбәләр.* Г.Әпсәләмов

◊ **Чебеш алып китәргә йөргән тилгән шикелле** Бик күзәтеп, сагалап һәм ашеренеп тә тормыйча. *Айсылу өйләрендә ялгызы гына калган чакларда, чебеш алып китәргә йөргән тилгән шикелле, алар өе турыннан да бик еш узгалый башлады бу.* В.Нуруллин. **Чебеш алырга җыенган тилгән сыман** *к.* **чебеш алып китәргә йөргән тилгән шикелле**. *Әхәт абый, торган саен дәртләнә барып, чебеш алырга җыенган тилгән сыман, кунак кыз тирәсендә бөтерелә башлады.* Г.Бәширов. **Чебеш атлап чыгарлык** Сай (сулыклар тур.). *Без яшәгән җирдә чебеш атлап чыгарлык инеш бар.* А.Хәлим

**ЧЕБИ** *и.* 1) Тавык яки тавыксыманнар отрядыннан булган кайбер кошларның балалары. *Абзарда сине тәкә сөзеп ега, лапас астына керсәң, коточкыч кабарынып, дулап, өстеңә чеби анасы ташлана.* Г.Бәширов. *Көне-сәгате җиткәч, бөре ачыла, тавык йомыркасын ватып, алтын сары чеби ялалып чыга...* А.Гыйләҗев

2) Яшь тавык. *Аннан соң [эт], алга ыргылып, тәү тартылуда ук юан чылбырны шартлатып өзде дә кунакчага менми калган бер яшь чебине ботарлап атты.* З.Хөснияр. *Чеби итен дүрт өлешкә бүләргә.* Ватаным Татарстан // Ашамлык итеп әзерләнгән яшь тавык ите. *Кыздырган чеби белән бәрәңге ашау*

3) Язгы суда, җилдә, салкында йөргәндә аяк-кулларның тиресе яргаланып барлыкка килгән вак-вак җәрәхәтләр. *Аягыңа ник кимәдең? Чебиләреңә кадәр күренеп тора. Кар өстендә кем ялантәпи йөри?* В.Нуруллин. *Язгы сулар белән бергә чыккан шул чебиләрнең әрнүенә төне буе елап чыккан малайларны әнкәләре әллә ничә тапкырлар эссе мунчада чабып, акырта-акырта*

*аякларын кайнар сулы таска тыгып, мунчала белән ышкып юса да, чебиләр барыбер җәй уртасы җитмичә бетми.* З.Зәйнуллин

4) **чебием** *тарт. форм. к.* **чебеш** (*4 мәгъ.*). *Әмир (кызны кочагына кысып): «Анысы синә һәйкәл куярлык инде, ике ел көткәнең өчен. Чебием минем!»* З.Хәким. *Назлый мине әбием, Иркәләп ул чакыра: «Килче монда, чебием».* Г.Хәйруллин

**ЧЕБИЛӘ́Ү** *ф.* Кул-аякларга чебиләр (*3 мәгъ.*) чыгу; кул-аяклар чебиләр белән каплану. *Хәтерлисеңме, яз көне, яланаяк йөреп, аякларың чебили иде ---.* Д.Салихов. *Куллар салкын җилдә ярылудан гына түгел, витамин җитешмәүдән дә чебили.* Мәдәни җомга

**Чебиләп бетү** Бик нык чебиләү. *Хәзер яхшы, ачык белмим – шул вакыйга узгач укмыдыр, аннан бераз соңракмыдыр – ул бөя бөяү, бәрәңге пешерүләрне ташладык, чөнки яланаяк гел сутлы юеш балчык эчендә йөреп, аяккуллар ярылып, чебиләп беткән, аны бетерү өчен туңмайны эретеп майлаган майның ачыттыруы йөрәгемә төшкән иде.* Г.Камал. *Капка янына килгәч, пыялачы күрде: малайның аяклары чебиләп беткән.* А.Гыйләҗев

**Чебиләп чыгу** *к.* **чебиләп бетү**. *Бер җәйдә, көннәр буе су буенда яланаяк чаба торгач, икесенең дә аяклары чебиләп чыкты.* Р.Габделхакова

**ЧЕБУРЕК** *и.* Гадәттә сарык фаршыннан тәмләткечләр салып майда кыздырып пешерелә торган яссы бөккән. *Син яраткан чебурекларны пешергән идем, улым.* Р.Сәгъди. *Адым саен чәйханә, адым саен шашлык кыза, мантый, чебурек пешә.* Р.Габделхакова

**ЧЕГӘН** *и.* 1) Күчмә яки ярымкүчмә төркемнәр булып төрле илләрдә яшәүче һинд чыгышлы халык исеме; шул халыкның бер вәкиле. *Габдерәшит бабай аюларның икесен дә чегәннәргә сатып җибәрде.* Г.Рәхим. *Аны белү өчен, биш сумыңны тотып, багучы чегән карчыгы каршына да барып торасы юк.* А.Хәсәнов

2) *күч.* Бер урында гына төпләнеп яшәмичә, еш күчеп йөрүче кеше. *Чегәнгә әйләнү*

3) *күч.* Әрсез, бәйләнчек, хәйлә яки башка юл белән үзенекен итә торган кеше. *Чегән икәнсең, бирмим дигән әйберне дә алдың бит*

◊ **Чегән арбасыннан төшеп калган** Каратутлы кеше турында. *Кырым татары тумасы, әйтерсең чегән арбасыннан төшеп калган: каратут йөз, очкын чәчеп торган күзләр, бөтен барлыгыннан ургып чыккан энергия ---.* Г.Гомәр. *Ник дисәң, ул кыз кара тутырлы, тәне дә кап-кара, аны үз әбисе дә, чегән арбасыннан төшеп калган, диеп шаярта.* В.Ильясов. **Чегән тормышы** Еш күчеп йөрүче, юлда күп йөрүче кешеләр тормышы турында. *Болай да өч ел чегән тормышында яшәттем инде ул бичараларны.* В.Нуруллин. *Синең, Гөлфая, үзеңнең дә хуҗалык эшендә гамең юк, ирең дә шундый бер зиһенсез булса, гомер буе җылы почмак күрмәссез, чегән тормышында яшәрсез.* Г.Әпсәләмов

**ЧЕГӘ́НЧӘ** *рәв.* **1.** 1) Чегән телендә. *Чегәнчә сөйләшү*

2) Чегәннәргә хас булганча. *Ләкин Асия күбрәк чегәнчә яки һиндча муеннарын, иңбашларын уйнатып биеде.* Г.Әпсәләмов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Чегән телендә булган. *Чегәнчә җыр*

2) Чегән халкына караган

**3.** *и. мәгъ.* 1) Чегән теле. *Чегән хатыны үз телендә мыдырдый, мин «тәрҗемә» итәм. Чегәнчә белүем – кытай, итальян чамасында, ишеткән дә юк иде.* Ш.Галиев

2) Чегәнчә бию. *Барый Тарханов чегәнчәне искиткеч оста бии дә иде.* Х.Сәлимҗанов

**ЧЕ́ДДЕР** *и. ингл.* Саргылт яки ак төстәге цилиндрик формадагы каты сыр төре. *Соусны болгата-болгата тагын бер минут утта тотабыз да, чеддер сырын салып, әйбәтләп болгатабыз һәм уттан алабыз.* Сөембикә

**ЧЕК** *иярт.* Металлга кечкенә генә металл әйбер, бәллүргә бәллүр һ.б.ш. бәрелеп алганда чыккан тавышны белдерә

**ЧЕК** *и. ингл.* 1) Агымдагы счёттан күпмедер сумма акча күчерү яки бирү турында кертемченең күрсәтмәсе язылган һәм имзаланган рәсми документ. *Тиешле сумманы Дәүләт банкысындагы счётыгызга күчерергә дип, чекларыбызны да язып китердек.* Т.Гыйззәт. *[Официант:] Чек кына яза аласыз.* Д.Салихов

2) Сатып алынган товар өчен түләнгән акча күләме күрсәтелгән талон. *Товар чекларын Фердинанд әфәндегә бирегез, тиене-тиенгә туры килсен!* А.Гадел. *Кагыйдә буенча, товар сатканда, сез сатып алучыга чек бирергә тиешсез. Кая чегыгыз?* Д.Булатова

**ЧЕКА́НКА** *и. рус* 1) *к.* **чүкү**. *Мин Казанның чеканка осталары иҗат иткән татар кызы портретын алып килдем.* Г.Ахунов

2) Чүкеп бизәкләр төшерелгән металл эшләнмә; чүкелмә. *Кызыксынмаслык та түгел: авторның буяулар белән ясалган рәсемнәре белән беррәттән чеканкасы да, ягъни металлга бизәкләр төшереп эшләнгән әсәрләре дә куелган иде.* А.Хәсәнова

3) Үсемлекнең җимеш бирүен арттыру яки тизләтү өчен, төп сабакның югары өлешен яисә ян-якларын кисеп алу, кырку

**ЧЕКА́НКАЛАУ** *ф.* Чеканка ясау. *Халыкның мул тормышта яшәвен күрсәтеп торган йортлары гына түгел, бизәкләп (кайберләре чеканкалап) эшләнгән биек тимер капкалары --- да дәлилли.* Мәдәни җомга

**Чеканкалый башлау** Чеканкаларга тотыну

**Чеканкалап бетерү** Чеканкалауны тәмамлау

**ЧЕКЕЛДӘ́Ү** *ф.* Металлга кечкенә металл әйбер, бәллүргә бәллүр берничә тапкыр бәрелүдән өзек-өзек тавыш барлыкка килү; чек-чек итү. *Машинаның корыч маңгае тирләп чыкты. Машина чекелдәде, тәкелдәде, уфылдады.* Г.Афзал. *Стаканнар стаканнарга бәрелеп чекелдәде, зәһәр сыеклык бугазны яндырып үтте.* Ф.Хуҗин

**Чекелдәп алу** Кинәт чекелдәү

**Чекелдәп кую** Бер тапкыр чекелдәү

**Чекелдәп тору** Туктаусыз чекелдәү

**Чекелди башлау** Чекелдәргә тотыну

**ЧЕКЕРӘЕП** *рәв.* Күзгә ташланып, аерылып, ачык күренеп. *Тәминдар байның ташпулаты әле генә җитештерелгән, энәдән-җептән генә чыккан булганга күрә, кояш күзендә чекерәеп, балкып-масаеп утыра иде.* Г.Ахунов. *Яшел төстәге капкада әллә каян чекерәеп, аермачык булып күренеп тора [ак чәчәк].* З.Хөснияр. *Чана эзләре төшкән ак кар өстендә кара тун чекерәеп күренә иде.* Р.Низами

**ЧЕКЕРӘЙТҮ** *ф.* Текәү, төбәү, алмыйча карап тору (күзләрне). *Шофёр, тәмәкесен капкан килеш, күзләрен чекерәйтеп, фотога текәлде.* Ш.Шәйдуллин. *Талхәветдин күзләрен зур итеп ачып та, чекерәйтеп тә карап карый ---.* А.Хәлим

**Чекерәйтә башлау** Чекерәйтергә тотыну. *Зифаның күзләрен чекерәйтә башлавын шәйләп өлгерде, ахрысы, оста гына үгетләүгә күчте ---.* В.Нуруллин

**Чекерәйтә төшү** Бераз чекерәйтү. *Әллә ул түгелме соң бу дип, күзләремне чекерәйтә төшеп кабат карап алдым: шул үзе, җор күңелле дустым, кем булсын инде.* З.Дәүләтов. *Таҗылбанат, куе дегет кебек күзләрен чекерәйтә төшеп, бер мизгел киленenә карап торды.* М.Хәбибуллин

**Чекерәйтеп алу** Азга гына чекерәйтү. *Ничек кенә алдаламый безне, Үрти, көлә, юри шаярта, Чекерәйтеп ала кайчак күзне, Ә аннары – йөзен каралта.* Ф.Яхин

**ЧЕКЕРӘЮ** *ф.* 1) Гаҗәпләнүдән, куркудан, ачудан һ.б.ш. хисләрдән күзләр зур итеп ачылу. *Альбертның ачудан күзләре чекерәйде.* З.Мәхмүди

2) Текәлеп, төбәп карап тору. *Ул туп-туры Хәйрүш каршына килеп басты да чекерәеп тезеп китте: – Тагын эчтеңме, ә? Чөмердеңме, сәрхуш?..* Н.Хәсәнов. *Юлга карап чекерәйгән, әйтерсең күршесенең сүзенә колак та салмый.* Б.Камалов

3) Төбәлеп, текәлеп караудан күзләр ару. *Терсәкне тешләп булмай аны, абзый кеше, тотынгансың икән, күзләрең чекерәйгәнче ясыйсың инде хәзер.* Р.Мөхәммәдиев

4) Озак вакыт төбәлеп, күз талдырып нидер эшләү. *Хатынының көнетөне чекерәеп утыруларының дөнья көтәр өчен никадәр кирәкле икәнен ул инде күптән төшенгән иде.* Ф.Яруллин

5) *күч.* Ялтырап күренү, җемелдәп тору. *Йолдызлар чекерәйделәр. Тизрәк яктырып янасылары килә. Ай калыкты.* М.Хуҗин. *Зәңгәр күк йөзендә хәзергә Ай балкый да, Чулпан чекерәеп яна.* С.Поварисов

**Чекерәеп алу** Беразга чекерәю. *Такта янында лекция сөйләүче галим, аның тәрәзәгә карап утыруына эче пошып, әллә ничә тапкыр сөзәрдәй булып чекерәеп алган икән.* Р.Газиз

**Чекерәеп бетү** Бик нык чекерәю. *--- буш кибетләрдәге кием-салым, ризык-фәлән янына куелган ярлыкларны укый-укый чекерәеп беткән күзләрем торгынлык елларында ашаган шикәр шикелле шакмакланды ---.* Л.Лерон

**Чекерәеп кую** Кинәт чекерәю. *Иванның соры күзләре чекерәеп куйды.* З.Мәхмүди

**Чекерәеп тору** Озак вакыт чекерәю; әле, хәзер чекерәю; күзгә бәрелеп тору. *– Кит каршымнан! – дидем мин, бар көчемә акырып. – Чекерәеп торма, караелан!* В.Нуруллин

**ЧЕКИСТ** *и. рус тар.* 1) Контрреволюциягә, саботажга, спекуляциягә каршы көрәшү өчен 1917–1922 елларда эшләп килгән гадәттән тыш комиссия хезмәткәре. *Чекистлар, бабамның мулла булуын белеп, безнең өйдә тентү ясыйлар, әмма гаепләрлек берни дә тапмыйлар.* Р.Вәлиев

2) СССРда дәүләт куркынычсызлыгы системасы хезмәткәре. *Фин сугышында чаңгычы, Бөек Ватан сугышында чекист булган.* С.Шәрипов. *Алар белән танышкан хатын-кызлар да безнең чекистларның күзәтүе астында.* Р.Кәрами

**ЧЕ́К ИТҮ** *ф.* Чек сыман тавыш чыгару. *Гарифулла абзый сүзсез генә урыннан күтәрелде, сүзсез генә тышка чыгып керде һәм сүзсез генә, мич арасында электр утын чек итеп кабызып, юынгычның су ага торган тимерен шалдыр-шолдыр китерә-китерә, ач яңакларын, ияк асларын сабынлый башлады...* А.Хәлим. *Күтәрүләр күңелле икән, Бокалларны чек итеп...* Г.Каюмов

**ЧЕКРИ** *с.* Нык төбәлеп карый торган, чыгынкы, чекерәеп торган (күз тур.). *Безнең группада тагын Хәйруллин дигән егет тә бар. Кечкенә генә буйлы чекри күзле, шактый ачы телле.* А.Расих

**ЧЕ́К-ЧЕК** *иярт.* Металлга металл, бәллүр берничә кат бәрелгәндә һ.б.ш. очракларда чыккан тавышларны белдерә

**ЧЕ́К-ЧЕК ИТҮ** *ф.* Чек-чек килгән тавышлар чыгару. *--- ике ир заты кайнаша. Берсе баскычка менеп баскан да чек-чек итеп кирпеч чокый.* В.Нуриев

**ЧЕ́К-ЧЕК КИЛҮ** *ф. к.* **чек-чек итү**. *Нияз белән Илгизнең, сәгатьне колакларына куеп: «Әти, чек-чек итеп йөри», – дип сөйләнеп йөрүләре тагы да искә төшеп сагындырдылар.* Ватаным Татарстан. *Әйтерсең лә бәләкәй тупчыкның, үзенә хас тавыш белән, уен өстәлләренә бәрелеп, вакыты белән паркетка да килеп төшеп, чек-чек килеп торуы спортчыларга темпны киметергә мөмкинлек бирмәде.* Бөгелмә авазы

**ЧЕЛ** *и. диал.* Кышын ак төскә кергән көртлек

**ЧЕЛӘЙТҮ** *ф. гади с.* 1) Текәлү, күзен кыса төшеп карау. *[Сабира:] Кеше баласына күз челәйтмиләр инде.* А.Гыйләҗев. *– Авылда Әнсардан башка да әллә нинди бөркетләр бар, – диде Сәет, күзләрен челәйтеп.* З.Хәким

2) *күч.* Һәркем күрерлек итү, ачык тоту, күрсәтү. *[Столяров] Кайвакыт Якубның кулына бирәр китапны тотырганда: «Бусын кешегә бик челәйтмә!» – ди торган иде.* И.Гази

**ЧЕЛӘН** *и. зоол.* Ләкләкчәләр семьялыгыннан сазлыкларда яши торган озын муенлы һәм озын аяклы кош; *русчасы:* **цапля**. *Ә яр буенда, озын сыйраклары белән адымнарын санап-санап кына басып, бик эшлекле кыяфәттә торналар, челәннәр йөри.* А.Хәсәнов. *Кыштырдык тавышыннан камышлар арасыннан пар челән күтәрелде.* М.Рәфыйков

2) *күч.* Ябык, чандыр, озын буйлы кеше. *Бу вакытта инде аңа берәү дә «Челән!» дими, ул йомры иңбашлы, томрап торган, күк шикелле серле күзле чибәр кыз иде...* Ш.Маннапов

**ЧЕЛӘНАЯК** *и.* 1) Озын адымнар белән йөрү өчен, басып торырлык тупсалар кадакланган озын колга; *русчасы:* **ходули**. *Алдым да ике таяк, Ясадым челәнаяк. Барам атлап, биеп мин, Коймадан да биек мин!* Ш.Галиев

2) *күч.* Озын буйлы, озын нечкә аяклы кеше. *Ну кызык итте үзеңне челәнаяк: ничек чаба, артыннан умарта кортлары куа диярсең!..* Р.Ишморатова

**ЧЕЛӘЮ** *ф. гади с.* 1) Текәлеп карап тору. *Футбол уенында син миңа челәеп карадың!* А.Гыйләҗев

2) Кысылу, чепиләнү. *Чыпта суккан яшь кызларның Ике күзе челәйгән.* Бәет

3) Талу, чекерәю

**ЧЕЛДЕР** I *иярт.* Тәңкәләр һ.б.ш. металлдан эшләнгән вак нәрсәләр берберсенә тиеп алганда ишетелгән тавышны белдерә. *Мин чәчәкне түгел, ялгызлыкны – Сагышымны йомдым ул чакны. Челдер... Челдер... Синдер... Бердер... Күңелемдә шул чәчәкләр чыңы.* Ф.Яхин

**ЧЕЛДЕР** II *и.* 1) Челдер-челдер тавыш чыгара торган нәрсә; шөлдер. *Күзләренең нуры сүнеп барган Бер ат йөри елга буенда. Йөгәненә таккан челдерләрнең Челтерәве моңсу тоела.* Казан утлары

2) *диал.* Чәчкап. *Челдер тагу*

**ЧЕЛДЕРӘ́Ү** *ф. к.* **челтерәү**. *Чылтыр-чылтыр җиз йөгән шул челдери.* Зөлфәт

**ЧЕЛДЕРМӘ** *и.* Бизәү яки тавыш чыгару өчен, киемгә, уен коралына һ.б.ш.га беркетелә һәм челтерәп тора торган вак тәңкәләр.

**ЧЕЛДЕРМӘЛЕ** *с.* Челдермәләр тагылган. *Челдермәле беләзек минем беләкләремдә.* Җыр

**ЧЕЛДЕ́Р-ЧЕЛДЕР** *иярт.* Металлдан эшләнгән бик җиңел, юка әйберләр бер-берсенә бәрелеп-бәрелеп алганда

ишетелгән тавышларны белдерә. *Ул җиз кыңгырауларның авылның теге башыннан ук челдер-челдер килеп болай табан якынлашуы бала-чаганы, яшь-җилкенчәкне дәртләндереп, йокыдан уята ---.* Г.Рәхим

**ЧЕЛДИ́-ЧЕБИ** *с. гади с.* Вак-төяк, көче күп булмаган. *Крестьян хатыннары ирләр эшләгәнне рәхәтләндереп эшләп киләләр һәм кайбер челди-чеби ирләрдән артык итеп тә эшлиләр.* М.Бөдәйле

**ЧЕЛЕК** *и. бот.* Кузаклылар семьялыгыннан тау битләрендә үсә, сары чәчәк ата торган чәнечкеле куак (каты сабакларын себерке ясау өчен кулланалар); *русчасы:* **чилига**. *Бетон багана сыман почмаклы, сары кылчык кашлы, күзләре ниндидер оятсыз зәңгәрлек белән зәңгәрләнеп торган бу кешенең танау мөшкәләреннән генә түгел, хәтта эре җитәкчеләр генә кия торган затлы кыска тунының ачык изүе аша күкрәгеннән челек сыман эре кыллар тырпаеп чыккан.* А.Хәлим

**ЧЕЛЕМ** *и.* 1) Тәмәке салып тарту өчен кечкенә чокырдан һәм төтенен суыру өчен көпшәдән гыйбарәт әсбап; трубка. *Гыйлаҗи бабай, хикәясен тәмамлаган кеше сыман, сүнгән челемен кабызу өчен, кесәсеннән шырпы эзли башлады.* М.Хәсәнов. *Монда бөтенесе тарта: сигара, папирос, челем, тагын әллә нәрсәләрдән төтен чыгарырга өйрәнгән адәм баласы.* Т.Әйди

2) *к.* **чилим**

**ЧЕ́ЛЕНДЖ** *и. ингл. неол.* Блогерның үзе башкарган эш-гамәлне икенче берәүләргә кабатларга тәкъдим итүдән гыйбарәт Интернет ролигы жанры. *Әлеге җырлы гаилә Ютуб каналына даими рәвештә кызыклы видеолар, челенджлар элеп тора.* Сабантуй. *Әле берсеннән-берсе кызыклы, үзенчәлекле челенджлар дисеңме, әле яңа җырлар, клипларны, я булмаса шаккатмалы бәйгеләрме – Гүзәл белән Илдардан яңалык көт тә тор!* Әлмәт таңнары

**ЧЕЛЕ́СТА** *и. итал. муз.* Нәфис һәм нечкә шөлдер авазы чыгара торган клавишлы-бәрмә музыка коралы. *Яңа партитура зур, составлы оркестрда башкарыла, анда күпсанлы бизәгеч инструментлар (фортепиано, ике арфа, ксилофон, челеста, кыңгыраучыклар, саксофон, өчпочмак) һәм тамтам эшкә җигелә.* Казан утлары

**ЧЕЛЛӘ** *и. фар.* 1) Җәйнең 25 июньнән 5 августка кадәрге иң эссе яки кышның 25 декабрьдән 5 февральгә кадәрге иң салкын вакыты. *Ул [кояш] күтәрелгән саен, җирдә дә, һавада да иртәнге юешлек кимеде, җәйге чилләнең эссе көне кызганнан-кыза барды.* Г.Ибраһимов. *Былтыргы кышкы чилләдә аларның да ике тавыгы, безнең дә ике тавыгыбыз туңып үлде.* А.Хәлим

2) *күч.* Эсселек. *Двигатель суынгач, кабинада ниндидер чиллә башланасын белә ул.* Н.Әхмәдиев

3) *күч.* Берәр эшнең иң тыгыз, кызу вакыты. *Табын мул, кунакларның йөзе килгән, мәҗлеснең челләсе иде әле монда.* Р.Зарипов

◊ **Челлә кигәвене** Бәйләнчек кеше. *Киенеп-ясанып, кая бик иртәләдең болай, челлә кигәвене?* Р.Хәмид. *Челлә кигәвене кебек бәйләнчек залимнең бүген дә өянәге кузгалды.* З.Мәхмүди

**ЧЕЛЛӘ АЕ** *и. сөйл.* Август. *Мәгълүм булганча, август безнең климат зонасында җәйге кызу айларның берсе булып исәпләнә. Халык календаренда аны, июль шикелле үк, челлә ае дип тә атыйлар.* Н.Максимов

**ЧЕЛПӘРӘМӘ** *рәв.* Бик вак кисәкләргә бүлгәләнеп. *Пыялалары челпәрәмә килгән кабинадан шофёрның бинт белән уралган канлы башы күренә.* Г.Әпсәләмов. *Шул кыска гына мизгел эчендә нәрсә булганын аңлап өлгермәсәм дә, каютамның тышкы як стенасы эчкә сытылып керүен, сулъяк шлюпканың челпәрәмә килүен күреп өлгергән идем инде.* М.Юныс

◊ **Челпәрәмә килү** Юкка чыгу, тормышка ашмау. *Чукынып китсен фән, чәнчелеп китсен завод, челпәрәмә килсен эшкә ашмас хыяллар!* А.Гыйләҗев. *Минем дә иң кыйммәтле, иң изге уйларым челпәрәмә килделәр.* И.Салахов. **Челпәрәмә китерү** Юкка чыгару. *Бер кичтә күрше хатыны кереп, аларның бу уйларын да челпәрәмә китерде.* К.Тимбикова. *Сөйләүдән туктаса, Искәндәр авызын ачар да аның бар хыялларын челпәрәмә китерер дип уйлады, ахрысы, сүзләрен йота-йота, кабаланакабалана сөйләде.* Р.Вәлиев

**ЧЕЛТӘР** *и. фар.* **1.** 1) Бизәкләре күзәнәкләп бәйләнгән эшләнмә. *Аларның кайберләре биредә дә челтәр бәйли, чигү чигә.* Г.Әпсәләмов. *Лилия Кәбированың шулай ук төрле чиккән, челтәр энәсе белән бәйләгән эшләнмәләре бик күп.* Ватаным Татарстан. *Чигү серләренә әнием төшендерсә, челтәр энәсе белән эшләргә әбием өйрәтте.* Кәеф ничек?

2) Күзәнәк-күзәнәк итеп яки бизәкләп тукылган яисә бәйләнгән үтәкүренмәле җиңел тукыма

3) Шундый тукымадан эшләнгән тәрәзә пәрдәсе. *Автобуста кайтканда, кинәт Азат фатирындагы яңа тәрәзә челтәре күз алдыма килде.* А.Тимергалин. *Ишектән керү белән сулда – кара пианино, каршыдагы тәрәзәдә – чәчәкле арзан челтәр.* Д.Булатова

4) Бик вак күзәнәкле бит япмасы. *Шунда ук битен-күзен куе челтәр астына яшергән төрек хатын-кызлары да күренгәләп китә иде.* М.Галәү. *Люция битендәге челтәрен күтәрмәде, хәтта минем алда да ачылырга теләмәде.* М.Маликова

5) Тимерчыбык, бау һ.б.ш. нәрсәләрне үзара кисештереп үреп ясалган һәм төрле максатларда кулланыла торган җайланма. *Төнлекне япты, кояш карамаган якларның киезләрен бөтенләй күтәреп, өч яктан кирәгәләргә челтәрләрне сөяде.* Г.Ибраһимов. *Теге ир үз өстенә тимер челтәрләр белән бизәлгән кыска, күн бишмәт шикелле япма киеп алган, әмма җиңнәре юк.* В.Имамов. *Зуррак малайлар челтәр тартып волейбол уйный, кызлар өер-өер булып сөйләшеп утыра, วаграк бала-чага велосипедта куыша.* А.Гыймадиев

6) Металл чыбыклардан күзәнәк-күзәнәк итеп эшләнгән рәшәткә. *Чебиләр үскән арада, ферма әйләнәсен тимерчыбыктан үрелгән челтәр белән урап куйдылар.* К.Кәримов. *[Йорт] Тауга менеп барган юлның уң ягына, аз гына уйсурак урынга утырган, урам яктан яшелгә буялган тимерчыбык челтәр белән уратып алынган.* М.Вәлиев

7) Агачны кисеп, уеп ясалган сыр, бизәк. *--- энҗе-мәрҗән дә, йортны бизәүче агач челтәрләр дә халыкның ач тамагын туйдыра алмый.* Р.Батулла

8) *сөйл.* Ятьмә. *Ул чөгә балыклары тутырылган челтәрен төшереп җибәрә.* Р.Батулла. *Сөзә торгач, челтәремә Эләкте бит бер балык. Шундый матур, шундый нәни, Карап тордым таң калып.* Р.Вәлиева

9) *сөйл.* Азык-төлек, төрле вак-төяк салып йөртү өчен җептән үреп ясалган сумка, сетка. *Әлеге кеше, эреле-ваклы капчыкларын, чиләкләрен, чемодан һәм челтәрен асып, --- дебаркадерга таба йөгерде.* Г.Бәширов

10) Тышкы күренеше белән үрелгән яки үзара кисешкән сызыкларга, җепләргә охшаган берәр нәрсә. *Нашләнең дә*

*күз төпләренә каралҗым челтәр кунды, йөзе сулды, чигәләрендә беренче кырау – ак бөртекләр елтырады.* А.Гыйләҗев. *Нурлар түбәндә, үзәнлектә яткан өянкеләрнең ябалдашларын алсу челтәр белән каплап, җем-җем кайнаша, бергә укмаша, яңадан тарала, бии.* А.Хәлим. *Суык бабай тәрәзәгә боз челтәрләрен чиккән.* Р.Мөхәммәдиев. // Тишекле-тишекле нәрсә. *Кар челтәре тиздән сүтелеп бетәр, Яшел фонтан атар агачлар ---.* М.Җәлил

11) Берәр территориядәге юллар, каналлар, линияләр җыелмасы. *---бүтән җирдә шәһәр челтәренә чыга торган телефон юк.* И.Хуҗин. *Климат акрынлап җылынган, бозлык эреп чигенгән, ә бу хәл елгалар челтәрендә, аларның агышында зур үзгәрешләр барлыкка китергән.* Р.Фәхретдинов. *Автоматтан 09 җыеп, шәһәр телефон челтәреннән 16 нчы оператор белән тоташтыруны килгән саен күп мәртәбәләр сорап карады ул.* А.Хәсәнов

12) Мәгълүмат алмашу һәм техник, информацион, программа ресурсларыннан куллану мөмкинлеге тудыру максатыннан коммутация чаралары һәм элемтә каналлары аша бер системага берләштерелгән компьютерлар җыелмасы. *Татар телле яшьләрнең бөтендөнья компьютер челтәре Интернетка чыгу диапазонын шактый нык киңәйтергә кирәклегенә басым ясалды.* Р.Зарипов

13) Берәр территориядә урнашкан бериш учреждениеләр, предприятиеләр җыелмасы. *Ул Казан электр челтәренең өлкән инженеры булып эшли.* Г.Мөхәммәтшин. *Бу – дөньядагы иң зур китапханәләр челтәре.* Р.Вәлиев

14) Бер тармакта төрле урыннарда эшләүче кешеләр. *Газетаның эшен яхшырту, аның сыйфатын күтәрү, хәбәрчеләр челтәрен киңәйтү буенча да Х.Ишбулатов – ару-талуны белмәс журналист.* М.Мәһдиев

15) *махс.* Берәр нәрсәнең тәртибен, эзлеклелеген чагылдырган таблица, схема. *Соңгысын, ягъни хезмәт хакын билгеләгәндә бөтенебез өчен закон бер – бердәм тариф челтәре, шуның нигезендә эшләнгән кулланма.* Р.Фәйзуллин

**2.** *с. мәгъ.* 1) Үтәкүренмәле яисә эре күзәнәкле җиңел тукымадан эшләнгән, тегелгән. *Челтәр якалы ак кофта, соры юбка кигән ул хатынның иң элек күзләренә игътибар иттем.* В.Нуруллин

2) Тышкы күренеше белән шундый тукымага охшаган. *Ул, шәүләсен йотарга маташкан челтәр бозларны чакчак кына ватып, ихатаны әллә ничә кат урады...* А.Гыйләҗев

3) Үзара кисешкән сызыклардан торган; берәр нәрсәдән үрелгән, бизәкләп ясалган. *Һәркайсында – тимер җептән үргән челтәр көбә, унысының берсендә – көмеш очлым, билләрендә булат ятаганнар, зур гөрзиләр.* В.Имамов. *Нурислам ярның теге ягында хан сараедай балкып утырган, челтәр бизәкле, зур капкалы йортка текәлептекәлеп карады.* А.Әхмәтгалиева

**ЧЕЛТӘ́РКАНАТЛЫЛАР** *и. күпл. зоол.* Ике пар канатларында челтәрсыман нечкә генә сеңерчәләре булган бөҗәкләр отряды

**ЧЕЛТӘ́Р КАТЛАУ** *анат.* Күзнең күпсанлы яктылыкны сизүчән күзәнәкләрдән тора торган эчке катлавы, ретина. *Күзнең челтәр катлавы җитәрлек күләмдә кояш яктысы алмаса, организмда артык күп мелатонин эшләп чыгарыла ---.* Мәдәни җомга. *Өлкән яшьтәгеләр арасында күзнең челтәр катлавы дистрофиясе еш очрый.* Әлмәт таңнары

**ЧЕЛТӘРЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **челтәрләү**. *Чатырлар, курчак өедәй, матур итеп төзелә, кәрнизләре челтәрләнә, тулаем буяла, аның эченә утыргычлар тезеп куела.* Т.Әйди

2) Күп урыннарда тишекләр барлыкка килү, тишкәләнү; берәр өслектә вак-вак тишекләр барлыкка килү. *Туп ядрәләре белән челтәрләнгән кырыбызга, ачлыкны итәгенә атландырып, корылык үрмәләгән еллар.* М.Җәлил. *Кар утырган, каралган, челтәрләнгән.* Г.Әпсәләмов. *Кояш инде кыздыра, Хәтта мичне уздыра. Гөрләвекләр ярыша. Эремим, дип карыша Челтәрләнгән кар көрте...* Л.Шәех

3) Төрле эзләр, сызыклар, юллар һ.б.ш. белән тулу. *[Карт:] Казыла торгач, җир асты челтәрләнеп, казылмаган җирләр саклык өчен анда-монда юан багана төсле булып кына калалар әле.* М.Гафури

4) Искерү, тузу; ертылып, тишелеп сәләмә хәлгә килү. *И туган йорт, син дә картаясың, Гомерләрең бара кыскарып. Түбә такталарың челтәрләнгән, Баскычларың бара кыйшаеп.* Г.Гайнетдинова. *Челтәрләнеп тузган чикмән һәм аның эчендәге иске бишмәт аркылы салкын җил үтеп, Миңлебайның кар көрәгән вакытта тирләгән тәне буенча суык йөгерә.* Н.Яһудин

5) *күч.* Начараю. *Менә син, хәтер дигәнең, тәмам челтәрләнгән хәзер.* Г.Гомәр

**Челтәрләнә бару** Торган саен ныграк челтәрләнү. *Челтәрләнә барган пар астыннан, яшәреп, уҗымнар баш калкыта башлый.* Саба таңнары

**Челтәрләнә башлау** Челтәрләнергә тотыну. *--- аларның агудан челтәрләнә башлаган үпкәләрен әлегә яшергән күкрәкләренә көзләрен орденны депутат Сабит Нургалиев кадый...* А.Гыйләҗев. *Әмир авылга язгы кояш җылысыннан карлар челтәрләнә башлагач кына кайтып керде.* В.Имамов

**Челтәрләнеп бетү** Бик нык челтәрләнү. *[Хәсби:] Чыннан да, моның нәрсәсен төзәтәсең инде, колаклары юк, кысалары челтәрләнеп беткән.* Т.Гыйззәт. *Мондагы юллар! Челтәрләнеп беткән...* Р.Сәгъди

**Челтәрләнеп тору** Әле, хәзер челтәрләнү; гомумән челтәрләнгән хәлдә булу. *Утрауларның кайберсендә камыштан корылган нindiдер куралар, киез өйләр күренә, пәрәвездәй булып, кибәргә эленгән балык аулары челтәрләнеп тора; кешеләр, терлекләр кыймылдаша.* Н.Фәттах

**ЧЕЛТӘРЛӘ́Ү** *ф.* 1) Нәрсәнең дә булса читенә челтәр тоту. *Ак ефәкнең читләре челтәрләп каелган.* И.Хуҗин. *Күлмәк җиңе очларын шул тиклем матур итеп челтәрләгән ки, бикәнең затлы киеменнән күз алмалы түгел иде.* М.Хәбибуллин // Челтәр бәйләү, үрү. *Кыш буе хатын-кыз киндер, алача суга: кызлар тугый, челтәрли иде.* Г.Исхакый. *Беренче очрашуга килгәндә, иңенә челтәрләп үрелгән кара шәл ябынган иде ул.* А.Мансуров

2) Агачтан эшләнгән предметларны, алтын яки көмеш бизәнү әйберләрен, кисеп, челтәр рәвешенә китерү. *Гөлбикә шулай да, әсәенең төсе итеп, уртасына кызыл якут куеп, саф көмештән челтәрләп эшләнгән ике зур чулпыны үзенә алып калды.* Ә.Еники. *Аларның челтәрләп ясалган тәрәзә наличникларын беренче тапкыр күргән кеше, хәйран калып, өй турларында беркавым туктап тормыйча үтми.* В.Нуруллин

3) Матурлау, сырлау, бизәкләү. – *Бар аның бисмилласы, абзый, бар. Әнә иң беренче битенә бик матур иттереп челтәрләп язган, – дидем.* Г.Бәширов

4) Бик күп урыннан тишү; берәр өслектә вак тишекләр барлыкка китерү. *Аннары яз кояшы койма буйларындагы*

*карны челтәрләп ясаган матур куышларга сокландык.* Г.Бәширов. *Кәбестә яфракларын корт челтәрләгән ---.* Н.Гыйматдинова

5) Төрле якка сузылган, төрлечә кисешкән юллар, эзләр, сызыклар, линияләр һ.б.ш. салу. *Калын катламнар һәм тирән ятмалардан мрамор, гранит, кварцит, гипс кебек төзелеш материаллары, төсле һәм сирәк металлар рудасы, тоз алынган җирләрне тимер, асфальт һәм таш юллар челтәрли.* З.Нури

6) Челтәргә охшату, челтәр кебек итү. *Кичләрен сопка итәкләрен челтәрләгән утлар аеруча матур булып күренә.* Р.Фәйзуллин. *Өстенә казылык я гөмбә, помидор телемнәре тезеп, уылган сыр, тәмләткечләр сибәләр, кетчуп яки майонез белән челтәрлиләр, сүрән утка куеп, өстенә капкач ябалар да сыр эрегәнче пешерәләр.* Мәдәни җомга

**Челтәрләп бетерү** Бик нык челтәрләү; тулысынча челтәрләү. *Тугымнарын ничек кенә челтәрләп бетерсәң дә, түгәрәк итми хәлең юк!* Ш.Галиев. *Күр, картаны ничек челтәрләп бетергәннәр...* А.Тимергалин

**Челтәрләп чыгу** Һәрберсен челтәрләү; ахырга кадәр челтәрләү. *Менә Арысланнар әсир төшкәч, аларны да шушы ябып көл булган авыл читенә китереп, ничектер исән калган озынча ат абзары әйләнәсен катлы-катлы тимерчыбык үрмәләре белән челтәрләп чыгарга куштылар ---.* Ш.Маннур

**Челтәрли башлау** Челтәрләргә тотыну

**ЧЕЛТӘРЛЕ** *с.* 1) Челтәрсыман итеп эшләнгән; күзәнәкле итеп бәйләнгән. *Челтәрле пәрдә аша үтә торган кояш нуры әллә кайчаннан бирле төрлетөрле бизәкле шәүләләр ясап уйнаса да, мин ялкауланам, иркәләнәм, әвәләнәм.* Г.Исхакый

2) Шундый челтәр эленгән, тегелгән. *Әнә алар – ап-ак челтәрле тәрәзәләр.* Г.Гыйльманов. *Челтәрле күлмәк*

3) Агачка, тимер һ.б.ш. сырлап, бизәкләп, рәшәткә итеп ясалган. *Масра юлыннан кайтканда исә, йорт зур ике тәрәзәсе, ак челтәрле наличниклары белән елмаеп тора.* М.Мәһдиев. *Сарайның икенче катында, челтәрле капкачлары ачып куелган бер тәрәзә төбендә япа-ялгыз сын утыра иде.* В.Имамов

4) Шундый рәшәткә тотылган. *Каршыңда челтәрле ак күпер.* М.Юныс

5) Тишек-тишек булган. *Күл өстендә батып бетмәгән зәңгәр челтәрле бозларга кунып, акчарлаклар төркеме утыра.* Т.Нурмөхәммәтов

**ЧЕЛТӘРЛЕ ЧҮМЕЧ** *и.* Төбендә тишекләре булган чүмеч; *русчасы*: **шумовка**. *Челтәрле чүмеч белән зур табаны да алып киттеләрмени?* Г.Ибраһимов

**ЧЕЛТӘ́Р СӨЯК** *и. анат.* Умырткалы хайваннарда баш сөягенең нерв җепселләре үтү өчен бик күп тишекләре булган алгы өлеше

**ЧЕЛТӘРЧЕ** *и.* Челтәр бәйләүче; челтәрләп тукучы. *Белгечләр, киләчәк буын хәзерге челтәрчеләргә сәер кешеләр итеп кенә түгел, бөтенләй акылсызлар итеп караячак, диләр.* Шәһри Казан

**ЧЕЛТЕРӘВЕК** *с.* Челтерәп торган. *Сәлам сиңа, кояш, сәлам, иртә. Сәлам сезгә, искән җилләрем. Сәлам сиңа, челтерәвек чишмә, Сәлам, урман, таныш үрләрем.* Г.Ибушев. *Тирә-юньне яңгыравык чыңга күмгән саф һәм челтерәвек тавыш...* А.Вергазов

**ЧЕЛТЕРӘ́Ү** *ф.* Челтер-челтер итү. *--- Челтер-челтер челтерәми Чишмәбез – Саеккан.* И.Юзеев. *Бозлар Җиһаншаның итекләре астында пыяладай челтерәп ватылалар.* Г.Әпсәләмов. *Кинәт күрше йортның шатыр-шотыр каерылган калай түбәсе очып барып юлга капланды, шиферлар меңгә теткәләнеп ярылды, тәрәзә пыялалары челтерәп коелды.* Н.Гыйматдинова

**Челтерәп алу** Бер тапкыр челтерәү; берара челтерәү. *Бәлки әле, минем җанны Урман булып яуларсыз. Бәлки әле, чишмә булып, Бер челтерәп алырсыз!* Ф.Җамалетдинова. *[Стаканнарның] Берсе урыныннан күчкәнне сизде-реп челтерәп алды.* Н.Хәйдәрова

**Челтерәп китү** Кинәт челтерәү. *Берсенең тавышы бигрәк тә матур. Көлгәндә челтерәп китә.* Г.Гыйльманов

**Челтерәп кую** Бер тапкыр челтерәү; кинәт челтерәү. *Язмамның шушы урынына җиткәч, эшемне туктатып торырга тиеш булдым – ишек кыңгыравы челтерәп куйды ---.* Ф.Баттал. *Менә безнең капка келәсе челтерәп куя, һәм аннан, гәүдәсен бик төз тотып, бер карт килеп керә.* Р.Фәизов

**Челтерәп тору** Даими, бер өзлексез челтерәү; әле, хәзер челтерәү. *Аяк баскан саен алар әле көмеш тәңкә сыман зең-зең итеп, әле ярсу чишмә тавышы белән челтерәп тора.* В.Имамов. *Хәл белешеп, кесә телефоным челтерәп кенә тора.* Г.Гомәр

**Челтери башлау** Челтерәргә тотыну. *Кыш әле калын тунын салмаган, ә урман тургаеның тавышы чишмәдәй челтери башлый инде.* Г.Гыйльманов. *--- әче таңнан кесә телефоннары челтери башлый.* А.Гыймадиев

**ЧЕЛТЕ́Р-БЕЛТЕР** *иярт.* Металл кисәкләре бер-берсенә төрле кырлары белән бәрелеп-бәрелеп алганда барлыкка килгән тавышны белдерә

**ЧЕЛТЕ́Р-БЕЛТЕР ИТҮ** *ф.* Челтер-белтер килгән тавышлар чыгару

**ЧЕЛТЕ́Р-БЕЛТЕР КИЛҮ** *ф.* *к.* **челтер-белтер итү**. *[Габделхак] аякларына хром итек кигән, итек үкчәләренә челтер-белтер килеп торган түгәрәк ак калай кисәкләрен элгән булган.* И.Туктар

**ЧЕЛТЕ́Р-ЧЕЛТЕР** *иярт.* **1.** 1) Инеш, чишмә, гөрләвекләр кебек сай сулыклар тиз акканда, телефон чылтыраганда ишетелгән тавышны белдерә. *Тал төбендә салкын чишмә Челтер-челтер көн буе, Челтер-челтер көн буе.* Г.Ибушев. *Челтер-челтер, челтер-челтер телефон, Бу телефон миннән нәрсә тели соң?* Г.Мөхәммәтшин

2) Вак тимер яки пыяла әйберләр бер-беренә бәрелгәндә барлыкка килгән тавышны белдерә. *«Зәй» колхозы кырларыннан, җир аслап, унбер рәт челтер-челтер тимер торбалар уза.* Ә.Маликов

**2.** *рәв. мәгъ.* Челтерәп, челтер-челтер итеп, шундый тавыш чыгарып. *Челтер-челтер көлүләрең Һаман да истә әле...* И.Юзеев. *Челтер-челтер аккан чишмә авазлары белән аңа [прима-скрипкага] арфа кушыла.* А.Хәсәнов

**ЧЕЛТЕ́Р-ЧЕЛТЕР ИТҮ** *ф.* Челтер-челтер килгән тавышлар чыгару. *Кыя өстеннән челтер-челтер итеп су ага.* М.Хәбибуллин. *Челтер-челтер итеп инеш ага, Сикерешеп үтә тамчылар. Тезелешеп кайта каз-үрдәкләр, Әйтерсең лә нәни җырчылар.* Г.Гыйльметдинова

**ЧЕЛТЕ́Р-ЧЕЛТЕР КИЛҮ** *ф.* *к.* **челтер-челтер итү**. *Челтер-челтер килсен табын, Өстәлләргә тез дә куй... Кой әле, кой касәләргә, Бездә – бәйрәм, бездә – туй!* И.Юзеев. *Сарашлы елгасының югары очы тирәсендәге шарлавыгы да төнге һаваны яңгыратып суын шаулатты, чишмә дә, челтер-челтер килеп, таштан ташка сикереп, елга белән кушылып, бербөтен булырга ашыкты.* И.Нәбиуллина

**ЧЕМ** I *и. фар.* 1) Алка сабы (бөгәлҗәсе)

2) Үсемлекнең җимеше урнашкан сабак; җимеш сабакчасы. *Ник оныттың, ник оныттың соң син Чеме белән җиләк җыйганны?* Ә.Гаффар. --- *тәлгәшне югалтаннан соң, йөземнең иң эре бер бөртеген чеменнән аерды.* Р.Рахман

**ЧЕМ** II *кис.* Үтә, бик. *Сездә дә нәкъ бездәге кебек икән аның чем ак чәчәкләре!..* А.Гыйләҗев. *Бер тотам чем кара чәче маңгаена төшеп тора.* А.Тимергалин. *Үзең кара, кашың кара, Чем кара күзең. Яратам мин караларны – Бир, Ходай, түзем!* А.Хәлим

**ЧЕМЕРДӘ́Ү** *ф.* Тәндә, кайбер әгъзаларда җиңелчә чәнчү, калтырау тою; чымырдау. *Тәне чемердәде егетнең.* А.Хәлим. *Аркалар чыйрап чемердиләр иде.* Г.Рәхим. *Күзләрем чемердәгәнче укыйм.* Ю.Әминов

**Чемердәп алу** Аз гына, бераз гына чемердәү. *Баш очымнан, гөрселдәп, карга көтүе очып китте, куркынып, тәннәрем чемердәп алды.* Безнең гәҗит

**Чемердәп китү** Кинәт чемердәү. *Безнең һәркайсыбыз үз башыннан үлем куркынычларын кичергән, бик күп авыр хәлләргә очраган, ак финнарның ерткычлыкларын күп күргән булса да, тәннәребез чемердәп китте.* Г.Әпсәләмов. *Дистәләрчә кызыксынулы карашлардан оялуданмы, бу карашлардан үзенең арка үзәкләре чемердәп китүен тоепмы, Галия чытырдатып күзләрен йомды.* Д.Булатова

**Чемердәп кую** Бер тапкыр чемердәү. *Бу уйдан малайның арка җекләре чемердәп куйды.* Р.Фәизов. *Фатыйма аркасы белән тоя иде аның астыртын карашын, бөтен тәне чемердәп куя.* З.Кадыйрова

**Чемердәп тору** Әле, хәзер чемердәү. *Алда җимеш суы чемердәп торганда нинди чәй ул?* Ф.Абдуллин. *[Куас] Өсте ачык имән кисмәктә, хуш ис бөркеп, чемердәп тора.* Л.Зөлкарнәй

**Чемердәп үтү** Тиз арада бөтен тән, күзәнәкләр чемердәү. *Бармакларының җылы, йомры җисемгә кагылуы булды, бөтен тәне буйлап нидер чемердәп үтте, йөрәге калтырап, еш-еш тибә башлады.* Т.Гарипова

**Чемерди башлау** Чемердәргә тотыну. *Анда яшәгән елларымны искә алсам, әле дә каз тәне чыга, чәч төпләремә кадәр чемерди башлый.* Сөембикә

**ЧЕМЕ́Р-ЧЕМЕР** *иярт.* 1) Кайбер нәрсәләрнең әчеп чыгу процессында ишетелә торган тавышны белдерә. *Әче бал чемер-чемер утыра*

2) Кайбер әгъзаларда барлыкка килгән җиңелчә чәнчеп алуны белдерә. *Өлкән лейтенанттан аерылуга, зәһәр эчемлек чемер-чемер тән буенча тарала башлады.* З.Хөснияр. *Үзенең тәненә чемер-чемер салкын менә, үзе күрә, имеш.* Безнең гәҗит

**ЧЕМЕ́Р-ЧЕМЕР ИТҮ** *ф. к.* **чемердәү**. *Чәй арасында тел куәсенә генә ярарлык балы да әнә мич башында чемер-чемер итеп утыра.* Н.Әхмәдиев. *Аяк бармаклары чемер-чемер итте, бугазына кайнар кургаш тулды, сулышы авырайды.* А.Гыйләҗев

**ЧЕМЕ́Р-ЧЕМЕР КИЛҮ** *ф. к.* **чемердәү**. *Тәннәрем чемер-чемер килә башлый.* Р.Сәгъди. *Бармак очларым чемер-чемер килә.* Ф.Җамалетдинова

**ЧЕМЕТЕМ** *и.* **1.** 1) Чәчелүчән әйберләрнең ике-өч бармак белән алынган микъдары. *Башка капчыкларда таш булып кипкән бербөтен ипи, берәр пешерерлек кенә ярма, бер чеметем чәй, кипкән мүк җиләге, коры каен тузы, ут кабызырга чакматаш.* А.Хәсәнов. *Ул каруннан кыш көне бер чеметем кар да ала торган түгел!* К.Булатова

2) *диал.* Бөрмә. *Өстемдәге генә, ай, күлмәгемнең Чеметем өсләренә чеметем. Кодагый канатым, сизмисеңме әллә, Бирнә алырга ла өметем.* Җыр

**2.** *с. мәгъ.* Вак; кечкенә. *Ул вак, чеметем адымнар белән кырандас каршысына килеп туктады.* А.Хәлим

**3.** *рәв. мәгъ.* Аз гына. *Кайчакта үзеңчә үтә зурдан кубып уйланасың да уйланасың, ә табышың чеметем дә булмый.* М.Хуҗин. *Аз гына, чеметем генә коньяк эчмисеңме?* А.Гыйләҗев

◊ **Чеметем дә** Бер дә, аз гына да. *Нинди генә тизлектә очма, Ай бер генә чеметем дә артта калмый, гүя ул самолёт белән бербөтен, күзгә күренмәгән ниндидер көч аларны бергә бәйләп куйган.* З.Мурсиев

**ЧЕМЕТЕП** *рәв.* 1) Аз гына. *Ашны да чеметеп кенә капты.* Г.Әпсәләмов *Сабый кулындагы кәнфитен чеметеп каба да аннары уенчык атын сыйламакчы була.* Г.Галиева

2) Аяк очларына басып, җиңел генә (атлау, йөрү тур.). *Моңа кадәр гасырлар буе алар, матур, нәфис, гүзәлләр, үзләрен итәк тыемында тыеп, шундый ук гүзәл жир өстеннән чеметеп кенә атлаганнар булсалар, хәзер алар чеметеп атламый.* А.Хәлим. *Әби, әллә нигә борчылган йөзен киленгә таба борып, йөрмә арттан дигәндәй, кулларын югары күтәреп селкеде дә, вак кына, чеметеп кенә атлап, капкага табан юнәлде.* Л.Ибраһим-Вәлиди.

**ЧЕМЕТТЕРЕП** *рәв. к.* **чеметеп** (*2 мәгъ.*). *Вак-вак кына, чеметтереп кенә атлап, буен-сынын матур гына уйнатып төшеп килә, агай, без күзләребезне ала алмас булдык.* Г.Бәширов. *Аяклары да йорт эчендә кия торган киез башмакларда түгел, чеметтереп кенә баса торган туфлиләрдә бүген.* Р.Рахман

**ЧЕМЕТТЕРҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **чеметү**

2) Тәнне чеметкәндәге кебек ачыттырып, авырттырып алу. *Бияләй эченә поскан бармакларны суык чеметтерә.* Л.Лерон. *Кабат йөрәкне чеметтереп авыртырга, ашказаны өсте кисәргә тотынды.* З.Кадыйрова

3) *күч.* Авыр тойгы, тирән борчу уяту, үкендерү, кызгандыру. *Бичара хатын өчен чеметтереп күңел әрни, шул ук вакытта аңа ачу да килә иде.* Ә.Еники. *Ул да түгел, йөрәкне чеметтереп, кызларым искә төште.* Җ.Рәхимов

4) *күч.* Үткен сүзләр белән тәнкыйть итү; сүз белән рәнҗетү, төрттерү. *Гадәттә, кызлар авыл егетләренең читят кызлар белән йөрүен и яратмыйлар, шундук чеметтереп җыр чыгаралар ---.* М.Хәбибуллин. *[Мингалим] Исем-бүләкләргә хирыс каләмдәшләренә, җый, җый, теге дөньяда, бәлкем, иманлымы син, дип төпченмәсләр, югары исемлеме, дәрәҗәлеме, диярләр, дип чеметтерә иде.* Н.Гыйматдинова

**Чеметтерә башлау** Чеметтерергә тотыну. *Муенын, битләрен кабат кызган вак ком бөртекләре чәнчеп чеметтерә башлады.* Ш.Шәйдуллин. *Мең энә белән берьюлы чәнечкәндәй, су салкыны тәнне дә бик нык чеметтерә башлаган иде.* В.Нуруллин

**Чеметтерә тору** Кабат-кабат, һаман чеметтерү. *Кызның бармаклары аның тәненә тиеп киткән саен, кызның йомшак сулышы аның маңгаена бәрелгән саен, ул дулкын һаман күкрәкне чеметтерә тора иде.* Р.Батулла

**Чеметтереп алу** Бераз чеметтерү. *Бу хәл Михаил Сергеевичның кай төшендер чеметтереп алды, аз гына булса да, кәефен бозды.* И.Хуҗин. *– Сәнгатьчә булган икән, – дип чеметтереп алды Мәрьям, үзе дә сизмәстән.* М.Маликова

**Чеметтереп кую** Көтмәгәндә чеметтерү; бер тапкыр чеметтерү. *– Шулай да миннән булсын яхшылык: мә, як рәхәтләнеп! – дип чеметтереп куй-*

*ды куюын.* В.Нуруллин. *Фәнисәнең йөрәгеннәрсәдер чеметтереп куйды.* Г.Бәйрәмова

**Чеметтереп тору** Әледән-әле, даими чеметтерү; хәзерге моментта чеметтерү. *Инде шактый вакытлар үтсә дә, үзем олыгаеп барсам да, әтисезлек барыбер искә төшеп, йөрәкне чеметтереп тора.* Безнең гәҗит

**Чеметтереп узу** Баштанаяк, рәттән чеметтерү. *Рөстәм паша бүләк әсирнең каршына килеп басты, карашы утлы кисәү белән кагылгандай яндырып һәм чеметтереп узды.* В.Имамов

**Чеметтереп үтү** *к.* **чеметтереп узу**. *Бу юлы антенна, чыннан да, Мәзлуманың күзен чыгарырга килгәндәй, выжылдап узганда, борын очларын чеметтереп үк үтте.* Р.Рахман

**ЧЕМЕТҮ** *ф.* 1) Тәннең тиресен бармаклар белән эләктереп бик каты кысу. *– Чеметсәң, ныклап чемет, сыгылып китәрлек булсын, – ди Клара.* А.Хәсәнов

2) Берәр предметны тырнаклар яки бармак очлары белән генә эләктереп тоту. *Ул, алъяпкычының почмакларын чеметеп, чаң каккан көйгә биергә тотынды.* Г.Бәширов. *– Сагынып сөйләргә генә калачак ул! – диде дә, озын нәфис бармаклары белән рюмканың биленнән чеметеп кенә тотып, озаклап, сөзеп-сөзеп эчеп куйды.* В.Нуруллин. *[Әнисе] Мич артында сайрашкан чикерткәләр көенә кушылып, итәгендә тавыш-тынсыз гына орчык әйләндерә, бармак очларына чеметеп, кабадан йон тарта.* В.Имамов

3) Йон, мамык, чәч бөртеге кебек нәрсәләрне тырнак очлары белән эләктереп алу. *Бер мамык кисәге чеметеп алу*

4) Сибелүчән, таралучан нәрсәне бармак очлары белән алу. *[Бәрәңгене] Урталай сындырып, чеметеп кенә тоз сибәсең.* Г.Бәширов. *Фәтхулла түш кесәсеннән көмеш савыт чыгарды, ачып, чеметеп канәфер алды, уртына кыстырды.* А.Гыйләҗев

5) Иреннәр, томшык белән өзеп ашау (хайваннар, кошлар тур.). *Нургали капка турысындагы киртәдән дә сикереп менмәкче иде, ничә еллар бөерендә йөрткән ташын кузгатып, каз бибиләре чирәм чеметеп йөргән җиргә сырты белән кадалды.* З.Мәхмүди

6) *к.* **чеметтерү** (*2 мәгъ.*). *Салкын җил битне өтә, Колакларны чеметә, Бармакларны әрнетә, Ә-тә-тә-тә, биетә! Без бит кырда, без эштә, Тешләр тими тел-тешкә: Әт-тә-тә...* Г.Әпсәләмов. *Буран битне чеметсә дә, мин аны сизмим, җил күзенә карап торам...* А.Гыйләҗев

7) *күч.* Авыр тойгылар, борчылу хисләре уяту. *Сугыш кырларыннан килгән авыр хәбәрләр йөрәкне чеметкәләп, борчып торалар, якты уйларны күләгәләр каплый.* Г.Бәширов

8) *күч. к.* **чеметтерү** (*4 мәгъ.*). *Үткән-сүткәндә чибәр кызларны сүз белән чеметеп калырга яратучы алтынчы цех малайлары күрсеннәр: Луизаны заводның иң атаклы инженер-конструкторы озатып куя!* А.Гыйләҗев

**Чеметә башлау** Чеметергә тотыну. *Сабирадан, Закирдан, Солтан белән баладан котылуын, һәр эштә үзенең ирекле булуын уйлап шатлангаласа да, бу шатлыклар, аңарга уйламаганнан гына килеп, озакка бармый, аны тагы бер яктан кайгы чеметә башлый ---.* Г.Ибраһимов. *Чеметә башлагач, Фаил кулын тартып алды.* В.Гали

**Чеметеп алу** Кинәт чеметү. *Азат аны борып чеметеп ала, ул кычкырып җибәрә.* А.Гадел

**Чеметеп кую** Бер тапкыр чеметү. *Хәтта чак кына чеметеп куйгандай булалар.* А.Хәсәнов. *Әхәтнең йөрәген нәрсәдер чеметеп куйды.* А.Фәләх

**Чеметеп тору** Даими, еледән-әле чеметү; әле, хәзер чеметү. *Врач марш атлатты, Нәҗипнең күз алмаларын уңга-сулга йөрттерде, аска-өскә каратты, борынын чеметеп торды ---.* А.Гыйләҗев

**Чеметеп узу** Тиз арада чеметү. *Аның сул аягын шаян пуля чеметеп узды, ләкин ул үзе бер генә немецны да үтерә алмады.* Г.Кутуй. *– Күр әле теге атларны! Матур бит, әйеме? – дигән сүзләр колак читемне чеметеп узалар.* А.Мансуров

**Чеметеп чыгу** Тулысынча, башыннан аягына кадәр чеметү; тегеннән-моннан чеметү, төрле җирләрдән чеметү. *Үзенчә шаярырга ниятләведер инде: салкын җил, тунның сәдәпләре арасыннан үтеп кереп, ирнең гәүдәсен чеметеп чыкты.* А.Фәләх

**ЧЕМЛӘП** *рәв.* Чеме белән. *Сиңа чемләп җиләк җыйдым Таныш алан читендә.* Р.Имаев

**ЧЕМЛӘ́Ү** *ф.* Җиләк-җимешне чеменнән аеру, чикләвекне кәшәнкәсеннән чистарту. *Болар: калай тартмада, сандык төбендә саклана торган кипкән, чемләгән чикләвек, тозлаган каз --- һәм, әлбәттә инде, умарта балыннан ясалган ачы бал.* М.Мәһдиев. *Татлы җимешләрне касәгә чемләп, әнигә бирдем.* Сөембикә

**Чемләп бетерү** Тулысынча чемләү

**ЧЕМЛЕ** *с.* Чеме белән бергә җыелган. *Чемле шомырт*

**ЧЕМОДАН** *и. фар.* Юл йөргәндә әйберләр салу өчен, күннән яки башка төр чыдам материалдан эшләнгән, тоткалы, кайчакта тәгәрмәчле өсте ябулы тартма. *Сылу гына кызлар Дамир белән безгә дә каш сикерткәлиләр хәзер, аулак өйгә чакыралар, чиккән кулъяулык биреләр, ап-ак өч пар пирчәткәм агач чемодан төбендә ята...* А.Гыйләҗев. *Исеме аталганнар, кайсысы киндер капчыгын, кайсысы фанер чемоданын күтәреп, сафка тезеләләр.* З.Зәйнуллин

**ЧЕМОДАНЧЫ** *и.* 1) Чемодан ясаучы

2) *күч.* Вокзал карагы, чемодан урлаучы

**ЧЕМОДАНЧЫЛЫК** *и.* Чемодан ясау һөнәре

**ЧЕМПИОН** *и. фр.* 1) Спортның берәр төре буенча ярышта җиңгән кешегә яки командага бирелә торган дәрәҗә; шундый дәрәҗәгә ия спортсмен яки команда. *Харап булмый ни, елның елында чемпион булган команда ярышта күренмәсен әле?!* В.Нуриев. *Екатеринбург, Владикавказ шәһәрләрендә узган Россия чемпионатларында призлы урыннар ала, 1997 елда Азов шәһәрендә Бөтенроссия җәйге спорт уеннарының чемпионы була.* Г.Мөхәммәтшин

2) *күч.* Берәр эштә оста, алдынгы кеше. *Аның шундый гадәте бар. Комачауларга дигәндә – чемпион!* А.Гыйләҗев

**ЧЕМПИОНАТ** *и. рус* Билгеле төрендә спорт чемпионын билгеләү, беренчелекне ачыклау өчен уздырылган зур спорт ярышы. *Әнәс – Казанның атаклы ишкәкчесе, заманында Европа чемпионатларында катнашкан атказанган спорт мастеры.* А.Гыйләҗев. *Ул көннәрдә футбол буенча дөнья чемпионаты бара иде.* А.Хәсәнов

**ЧЕМПИОНЛЫК** *и.* Чемпион булу; чемпион дәрәҗәсе. *Футбол уенында да чын лидерсыз булмый әнә, чын лидерлы команда гына дөнья чемпионлыгына чыга – гап-гади хакыйкать бу.* М.Хуҗин. *Ләкин ул чакта ике судья кызыл лампа кабызды, һәм чемпионлыкка юлны яптылар.* Д.Гыйсметдин

**ЧЕМЧЕКЛӘНҮ** *ф. сөйл. к.* **чемчену** (*2 мәгъ.*). *Кукуруз арасында йөргән ике кәҗә, мутланып, башларын күтәреп карадылар да, исләре китмичә, һаман чемчекләнүләрендә булдылар.* А.Гыйләҗев

**ЧЕМЧЕКЛӘ́Ү** *ф.* 1) Чеметеп-чеметеп кенә, вак-вак кына итеп, азазлап кына ашау. *Яз кояшы, печән чемчекләгән тай шикелле, кар япмасын ялмый.* Ф.Сафин. *Алтын балыклар чемчекләп ямьсезли дә әле аларны.* Сөембикә

2) Кутырны, чуанны тырнак очлары белән казу, аны кубарып алырга маташу // Берәр нәрсәне казу. *[Бала] Шундук сикереп тора, юлына очраган бөтен нәрсәне төртеп төшерә ---, каера, аера, сындыра, каба, чәйни, йота, ваклый, чокый, чемчекли...* Ф.Сафин

3) *күч.* Берәр нәрсәне, мәсәлән, авыр, үкенечле вакыйганы, кабат-кабат искә төшереп, кемне дә булса борчу. *– Юлда энекәшеңне чемчекләп, талап кайтма, – диде.* А.Гыйләҗев

4) *күч.* Һаман орышып, бәйләнеп тору. *Туктаусыз тикшерү, чемчекләү*

**Чемчекләп тору** Даими, әледән-әле чемчекләү; әле, хәзер чемчекләү. *Адым саен аны чокып, чемчекләп тормасана!* А.Гыйләҗев. *Квартирада телефон юк, Рашат аны: «Әтиләр туктаусыз тикшереп, чемчекләп тормасын өчен юри керттермим», – диде.* Ф.Садриев

**ЧЕМЧЕНҮ** *ф.* 1) Ашамлыкны азаз кабып ашау; этеп-төртеп, сайланып кына ашау. *Алдыңа куйган ризыкны яманлый күрмә. Чемченеп тә утырма.* А.Хәсәнов. *Халидә тозлы суда ярып бәрәңге пешергән иде, малайлар әзрәк чемчеңделәр ---.* Н.Гыйматдинова

2) Үлән башларын гына кыеп ашап йөрү (терлек тур.). *Чирәмлектә чемченгән оя-оя казлар, ризасызлыкларын каңгылдашып белдереп, аңа юл бирде.* Н.Әхмәдиев. *Моны тәртә арасындагы үгез дә сизенде, ахрысы, һәрхәлдә, җигелгәнче әле шактый вакыт буласы икән, дигән фикер башына килгәндәй, ул тәртә янындагы камытлар, ыңгырчак-фәләннәрне таптап, чирәм чемченергә дип, лапас буена китеп барды.* М.Мәһдиев

**Чемченә башлау** Чемченергә тотыну. *Их, бирәсе иде чак кына чемченә башлаган колыннарга, бераз гына булса да, чәй урынына кайнатып эчәрлек хуш исле урман печәнен!* Н.Әхмәдиев. *Нәҗип, тезен чәнчеп, учындагы балдакны вакыт-вакыт караштырып, ямьсез, өметсез уйлар чоңгылына чумды, янына ук килеп үлән чемченә башлаган кәҗәне дә күрмәде.* А.Гыйләҗев

**Чемченә тору** Әлегә, нәрсәдер башланганчы, нииндидер вакыт җиткәнче чемченү. *Чемченә торсыннар, вакыт үткәрергә ярап тора ул.* К.Кәримов

**Чемченеп алу** Бераз чемченү. *[Җәйрән] Бер уҗым чемченеп ала да өч-дүрт тапкыр як-ягына карана.* А.Хәсәнов

**Чемченеп бетерү** Ахырга кадәр чемченү. *Башка кеше икенче блюдоны тәмамлаганда, әле ул салатны чемченеп кенә бетереп килә.* Т.Нәҗмиев

**Чемченеп тору** Күпмедер вакыт чемченү; әле, хәзер чемченү. *Чүмәләнең яртысы диярлек актарып ташланган, арырак өч-дүрт иярле ат чемченеп тора.* Ш.Шәйдуллин. *Хуш исле солы саламы чемченеп торган Микәй шундук башын читкә борды.* Р.Мөхәммәдиев

**Чемченеп утыру** *к.* **чемченеп тору**. *– Булмас дигәч булмас, яратмыйм мин шундый юк нәрсә белән чемченеп утыруны! – диган.* Г.Ибраһимов

**ЧЕМЧҮ** *ф. к.* **чемченү**. *Томаннан да аграк бер ат, башын җиргә төрткәләп, үлән чемчеп йөри иде.* Т.Нурмөхәммәтов

**Чемчеп бетерү** *к.* **чемченеп бетерү**. *Таңнарда чыклы үлән һәм яфрак әзләп, үзе бәйләнгән агачның кайрыларына кадәр кимереп, агач төбендәге чирәмне туфрагына тикле чемчеп бетерде.* В.Имамов

**ЧЕҢ** *иярт.* Металл, пыяла, бәллүр һ.б.ш. җиңел генә бер-берсенә тиеп алганда ишетелгән тавышны белдерә

**ЧЕҢГЕЛДӘТҮ** *ф.* 1) Чеңгел-чеңгел иткән тавыш барлыкка китерү. *Чеңгелдәтеп, Чехословакия рюмкаларына сала башлаган идем, ишек шакыйлар.* Г.Афзал. --- *Гөлчирә аларның икесе белән дә рюмкаларны чеңгелдәтеп чәкештерде дә ширбәтен вак-вак кабарга керешә.* Ф.Садриев

2) Гитара, мандолина һ.б.ш. музыка коралларында уйнау. *Мандолина чеңгелдәтү*

**Чеңгелдәтеп алу** Тиз генә чеңгелдәтү

**Чеңгелдәтеп җибәрү** Көтмәгәндә чеңгелдәтү; чеңгелдәтергә керешү. *Мандолина чеңгелдәтеп җибәрде*

**Чеңгелдәтеп кую** Чак кына чеңгелдәтү

**Чеңгелдәтеп тору** Әле, хәзер чеңгелдәтү

**ЧЕҢГЕЛДӘ́Ү** *ф.* 1) Металлга металл, бәллүргә бәллүр җиңелчә тиеп алганда һ.б.ш. очракларда барлыкка килгән нечкә авазларны белдерә. --- *ак айгырга атланган кызыл чикмәнле Пугач патша килә, яшел билбавына ике пистолет кыстырган, кызыл сәхтиян итегендә көмеш шпорлар чеңгелди ---.* Ф.Шәфигуллин. *Мескен кыз бик озак басып торыр иде, чеңгелдәп, кыңгырау шалтырады.* И.Салахов. *Хатыны чиләккә чеңгелдәп сауган сөт тавышыннан аны ишетмәде.* Н.Хәсәнов

2) Скрипка, мандолина, гитара, балалайка кебек музыка коралларының кыллары тирбәнүдән нечкә яңгыравык авазлар барлыкка килү. *Гитара чеңгелди*

3) Чинау, өрү. *Әнчекләрең чеңгелди*

**Чеңгелдәп алу** Тиз арада чеңгелдәү. *Хыялый егетнең уйларын хуплагандай итеп, өй кыегының бер читендә чыпчыклар нәни кыңгырау сыман чеңгелдәп ала.* Ф.Нәгыймов

**Чеңгелдәп җибәрү** Кинәт чеңгелдәү

**Чеңгелдәп кую** *к.* **чеңгелдәп җибәрү**

**Чеңгелдәп тору** Даими, әледән-әле чеңгелдәү; әле, хәзер чеңгелдәү. --- *бу тынгысыз музыкантның концерт белән бармаган җире, төрле зурлыктагы чеңгелдәп торган үз гармуннарын уйнамаган сәхнәсе калмагандыр.* Л.Хәмидуллин

**Чеңгелди башлау** Чеңгелдәргә тотыну

**ЧЕҢГЕ́Л-ЧЕҢГЕЛ** *иярт. к.* **чеңчең**. *Нәсимә бик елагач, муенына кечкенә кыңгырау тагып җибәргән идем, чеңгелчеңгел тавышы, аерылып, ерактан ук ишетелә икән.* А.Гыйләҗев. *Әллә нинди музыка яңгырый... Ул чеңгел-чеңгел ерактан ишетелә башлый ---.* Ф.Садриев

**ЧЕҢГЕ́Л-ЧЕҢГЕЛ ИТҮ** *ф.* Чеңгел-чеңгел килгән тавышлар чыгару. *Шулар арасында тиен сикереп уйнап йөри, көмеш күркәләрдән теллин-теллин, чеңгел-чеңгел иткән матур тавышлар яңгырап тора.* Көмеш кыңгырау

**ЧЕҢГЕ́Л-ЧЕҢГЕЛ КИЛҮ** *ф. к.* **чеңгел-чеңгел итү**. --- *бөтен түшендәге орден-медальләрнең чуты юк, талир тәңкәләр сырышкан чулпы кебек, атлаган саен чеңгел-чеңгел килеп торалар.* А.Гыйләҗев

**ЧЕ́Ң ИТҮ** *ф.* Чең кебегрәк тавыш чыгару. *Менә нәрсәдер чең итеп ишек тоткасына бәрелде.* Э.Шәрифуллина

**ЧЕҢК** *иярт.* Металлга металл, бәллүргә бәлләр тиеп алганда ишетелгән кыскарак нечкә тавышны белдерә. *Шулчак теге егет миңа чәркә сузды. Чеңк!..* Р.Галиуллин

**ЧЕ́ҢК ИТҮ** *ф.* Металлга металл, бәллүргә бәллүр тиеп алганда, кыска гына нечкә тавыш чыгару

**ЧЕҢЛӘ́Ү** I *ф.* 1) Нечкә чың барлыкка китерү; чыңлау, чеңгелдәү. *Кубәләктәй җиңел гәүдәле, һәрчак көләч, жырга-биюгә дигәндә чәчрәп торган Әнвәрә театрга кояштай балкып, кө-*

*меш кыңгыраудай чеңләп килеп керде.* Ф.Садриев. *Гүя скрипка кыллары – Чеңли җирдә чалгы чыңнары.* Р.Низамиев

2) *этн.* Йола буенча кияүгә озатыласы кыз һәм аның иптәш кызлары үтәгән сыктау, елау катыш җырлау. *Аны, кыз үзе чеңли белмәгәндә, йола таләбе буенча башкарганнар.* Р.Мөхәммәтҗанов

**Чеңләп алу** Тиз арада чеңләү. *Бездән алдарак кытай малайлары күтәреләл иде, калышмавыбызны күреп, үзләренчә чеңләп алдылар.* Кызыл таң

**Чеңләп кую** Бер тапкыр яисә кыска гына чеңләү

**Чеңләп тору** Өзлексез чеңләү; әле, хәзер чеңләү. *Казанымның күкләрендә Кояшсыз моң ачысы. Ә йөрәктә чеңләп тора Һаман яңгыр тамчысы!* Р.Низами

**Чеңли башлау** Чеңләргә тотыну. *Күзләрен йомарга да өлгермәде, бик ерактан теллин-теллин, келтер-келтер иткән тавышлар чеңли башлады.* Көмеш кыңгырау

**ЧЕҢЛӘ́Ү** II *и. этн.* Гаилә йолаларының берсе: кияүгә чыгасы кызны озатканда үтәлгән кыз елату йоласы һәм шуның җыры. *Кайсы самаклап, такмаклап әйтелә (яучы самагы), кайсы теләк теләү характерында (арбаулар), икенчеләре елау, сыктау (чеңләүләр һам сыктаулар) формасында бара.* Р.Мөхәммәтҗанов

**ЧЕҢЛӘҮЧЕ** *и. этн.* Чеңләүне (II) башкаручы, чеңләү йоласында катнашучы. *Чеңләүчеләр – шул ябынгычны тотып торучылар инде, бу йоланы белгән апалар, кыз ягы туганнары.* Казан утлары

**ЧЕ́Ң-ЧЕҢ** *иярт.* Металлга металл, пыялага пыяла, бәллүргә бәллүр берничә кабат тиеп алганда ишетелгән нечкә тавышны белдерә. *Черкиләр патшалыгы, чең-чең кылыч кайрап, төнге сугышка кузгалды.* Ш.Маннур. *Халит бабай тоткан бәләкәй чүкеч чең-чең диеп суга ---.* Р.Батулла

**ЧЕ́Ң-ЧЕҢ ИТҮ** *ф.* Чең-чең килгән тавыш чыгару. *Бәллүр рюмкалар чеңчең итте.* Ф.Садриев. *Сагынам мин Сабан туйларында Чең-чең иткән кыңгырау тавышларын.* Ф.Яруллин

**ЧЕ́Ң-ЧЕҢ КИЛҮ** *ф. к.* **чең-чең итү**. *Кузгалды ул – чең-чең килде көмеш шөлдер.* Р.Гамзатов

**ЧЕП-** *кис. к.* **чип-**. *Кыскача гына әйткәндә, бөтенләй чеп-чи наданнар.* Г.Камал. *[Амур (тамашачыларга):] Диләфрүз. Чеп-чибәр, чап-чая кыз.* Т.Миңнуллин

**ЧЕПЕЛДӘТҮ** *ф.* Күзләрне кысыбрак бер ачу, бер йому. *Ул аңа күзләрен чепелдәтеп, йомгалап карап торды ---.* А.Шамов // Иреннәрне, авызны чәпелдәтү

**Чепелдәтеп алу** Бераз чепелдәтү

**Чепелдәтеп кую** Бер тапкыр чепелдәтү

**Чепелдәтеп тору** Гел чепелдәтү; әле, хәзер чепелдәтү. *Ике учы белән сәке кырыена таянып утырган бабакай-әтием, мине күргәч, бераз гына авызын чепелдәтеп торды да үксеп елап җибәрде.* Ж.Тәрҗеманов

**ЧЕПЕЛТ** *с.* Туктаусыз бер ачылып, бер йомылып торган (күз тур.). *Бу хурлыкка ковбой Жора түзмәде, чепелт күзен көпшә итеп төзәде ---.* Р.Идиятуллин

**ЧЕПЕ́ЛТ-ЧЕПЕЛТ** *иярт. к.* **челт-челт**. *Кыз, шомырт кара күзләрен чепелт-чепелт китереп, барысына да күз салып чыкты.* Р.Сәгъди

**ЧЕПЕ́ЛТ-ЧЕПЕЛТ ИТҮ** *ф.* Күзләр бер ачылып, бер йомылып тору

**ЧЕПЕ́ЛТ-ЧЕПЕЛТ КИЛҮ** *ф. к.* **чепелт-чепелт итү**

**ЧЕПЕЛЧЕ** *с. к.* **чепелт**. *Ләкин җил юкка гына маташа, юкка гына хәленнән тая; юкка гына Бәдерниса карчыкның болай да чепелче күзләренә чүп кертергә омтыла.* А.Алиш

**ЧЕПЕР** *кис.* Шыр, бик. *Үзе дә чепер исерек ир хатынын тартып торгызды.* Шәһри Казан

**ЧЕПЕ́Р-ЧЕПЕР** *иярт.* Берәр сыеклыкны болгатканда, чөмереп эчкәндә чыккан нечкә тавышны белдерә. *Чепер-чепер сөт эчү*

**ЧЕПЕ́Р-ЧЕПЕР ИТҮ** *ф.* Чепер-чепер килгән тавыш чыгару. *Куян, кетеркетер итеп, агач кайрысы кимергән, ә песи, чепер-чепер итеп, сөт эчкән.* А.Алиш

**ЧЕПЕ́Р-ЧЕПЕР КИЛҮ** *ф. к.* **чепер-чепер итү**

**ЧЕПИ** *с.* 1) Кысылып кечерәйгән, кызарган, начар күрә торган (күзләр тур.). *Сез --- кечкенә генә чепи күзләрегезне челт-челт йомасыз да бәхет турысында хыялланасыз.* Г.Рәхим. *Тикмәгә генә, нәрсәдер өмет иткәндәй, чепи күзләрен чет-чет йомгалап, Сабирҗан ягына караштырып алмыйдыр...* М.Хәсәнов

2) *күч.* Уты кысылган; начар яна торган. *Сәке уртасында чепи лампа. Тирәсендә кызлар җырлыйлар.* Х.Назарова

**ЧЕПИКҮЗ** *и.* Күзләре ярымйомык, кызарып торган, начар күрә торган кеше. *Төнлә булса, караңгы, күрмәдем, дияр идең. Хәзер бит ярты чакрымнан юл күренеп тора. Их чепикүз, чепикүз!* А.Гыйләҗев

**ЧЕПИЛӘНҮ** *ф.* Күзләр начарлану; күзләр бетү; начар күрә торган булып китү. *Аңарчы әле синең бөкрең чыгар, тез башларың сөялләнеп катар, төннәрне йокысыз уздырып, күзләрең чепиләнер.* Г.Бәширов. *Мин күзләрем чепиләнгәнче көтәм, көтәм...* Н.Гыйматдинова

**Чепиләнә башлау** Чепиләнүгә табан үзгәрү

**Чепиләнеп бетү** Тәмам чепиләнү. *Көн карады Гөлниса, төн карады, күзләре чепиләнеп бетте, йөзе тәмам саргайды, тик бу юл белән дә терелмәде.* Р.Рахман

**Чепиләнеп калу** Ахырда чепиләнү. *Тыңлаучыны ышандыру нияте белән, гел күзлек киюдән чепиләнеп калган соры күзләренә дә кайгы-хәсрәт төсмере сирпи.* Т.Галиуллин

**Чепиләнеп тору** Әле, хәзер чепиләнү

**ЧЕ́П-ЧЕП** I *ымл.* Тавык чебиләрен чакыру авазы. *Чеп-чеп-чеп! Чебекәйләр, йомшаккайлар!..* А.Гыйләҗев. *Ярый, шук йомгаклар, карынгыз ачкач чыгарсыз әле... Чеп-чеп... Ә мин сезне тәмле ярма белән сыйлармын.* Г.Каюмов

**ЧЕ́П-ЧЕП** II *иярт.* Иреннәр чыпылдаган, дулкыннар ярга килеп-килеп бәрелгән, су өстенә суккалагандагы һ.б.ш. тавышларны белдерә

**ЧЕ́П-ЧЕП ИТҮ** *ф.* 1) Чеп-чеп килгән тавыш чыгару; чиелдау (чеби тур.). *Янәшәдә генә бертуктаусыз чепчеп итеп торган яңа борынлаган сары чебешләр дә һичкемне битараф калдырмады.* Ватаным Татарстан

2) Иреннәр чыпылдаганда, диңгез берничә кат ярга килеп бәрелгәндә, су өстенә суккалаганда чеп-чеп килгән тавышлар чыгару. *Диңгез, чеп-чеп итеп, Киң ярларга бәрелә-кагыла...* Ш.Фидаи

**ЧЕ́П-ЧЕП КИЛҮ** *ф. к.* **чеп-чеп итү**. *Чеп-чеп килеп йөргән сары чебиләр йөз процентка бәхетле, сабыйлар да шулай.* А.Тимергалин. *Әтәч кунган читәнгә, Тавык җырлый кетәктә, Чебиләре чеп-чеп килә, Их, матур соң бу иртә.* М.Әмирханов. *--- хәтер елгасындагы дулкыннар да чеп-чеп килеп дулкынлана ---.* Г.Гыйльманов

**ЧЕР** *иярт. к.* **чер-чер**

**ЧЕРӘШҮ** *ф.* Үзсүзләнү; үҗәтләнү; киреләнү. *Мулланың: «Мин ашамадым, ашыйм әле!» – диюенә дә, тәлинкәгә ике куллап черәшеп ябышуына да илтифат итүче булмады.* М.Галәү. *Шәйхенур*

*Газизович, менә бу иптәшләр сезнең янга керәбез дип черәшәләр.* А.Гыйләҗев

**Черәшә тору** Әлегә кадәр черәшү. *Гариф Ахунов әйтмешли, черәшә торгач, Карл Маркс урамындагы комсомол өлкә комитеты бинасын алдык.* Р.Вәлиев

**Черәшеп бетү** Бик нык черәшү. *Фәсхинур, черәшеп беткән ике кортканың, төенчек-чемодан күтәреп, олы юлга чыгып басканнарын күз алдына китерде дә хәсрәтле көрсенеп куйды.* Р.Рахман

**Черәшеп тору** Даими черәшү; әле, хәзер черәшү

**Черәшеп яту** *сөйл. к.* **черәшеп тору**. *Аклар бу бик әһәмиятле нокталарны бирмәскә черәшеп ята.* Г.Рәхим

**ЧЕРӘЮ** *ф. диал.* Төс-бит бозылу, чырай бозылу. *Ямьсезгә матур дисәң, ирәеп китәр, матурга ямьсез дисәң, черәеп китәр.* Мәкаль. *Черәеп карышты чирле карт.* А.Гыйләҗев

**ЧЕ́РВИ** *и. рус* Кызыл төстәге йөрәк сурәтләре төшерелгән уен кәрте масте. *Чөнки, уйнаганда, ул инде карталарны буби, кресты, черви дип түгел, әллә ниткән исемнәр белән атый.* М.Мәһдиев

**ЧЕРВО́НЕЦ** *и. пол. иск.* 1) 1917 елга кадәр Россиядә өч сумлык алтын; кайвакыт биш һәм ун сумлык тәңкә. *Икенче яктан шунысы уйландыра: алты йөз банкнот, диде ич, алтмыш червонец дигән сүз.* Ф.Хөсни

2) *сөйл.* Советлар Союзы вакытында ун сумлык кәгазь акча. --- *берничә елдан соң совет акчасының курсы тәмам ныгыгач, червонецлар чыккач.* А.Шамов

**ЧЕРВЯ́ГА** *и. рус* Червягалар семьялыгыннан эре яңгыр суалчанына охшаган кара төсле аяксыз җир-су хайваны

**ЧЕРЕК** *с.* **1.** 1) Череп таркалган; череп бозылган. *Бу көтүнең эчендә теге сары башлы, әйбәт киемле, черек тешле малай да бар иде.* Г.Ибраһимов. *Аланлыкта томан, яшен сугып сындырган черек агач янында еланнар...* А.Гадел

2) Авыру; авырудан таркалган, үз функциясен үти алмый торган. *Без дә Тукайны черек үпкәле, зәгыйфь, мескен итеп уйнамаячакбыз.* Р.Батулла

3) Яңгырлы, юеш, томанлы. *Алда салкыннар аяк киенгән черек көздә болай дим: «Туңма, туган! Туңма, рухташым!»* Р.Фәйзуллин

4) *күч.* Бозык, эчтән таркалган. *[Инсаф:] Мондый черек армиянең уставын мин танымыйм!* И.Юзеев. *Үткәннәрдән һаман кер эзлибез, Җимерелә черек бүгенгебез.* К.Булатова // Усал, ямьсез, бозык. *Синең черек телеңне эт тә ашамый, ахмак!* Н.Гыйматдинова // Нигезсез, зарарлы. *Мондый өметсез киләчәккә корылган тормышның черек фәлсәфәсе дә бар: исең киткән икән иске черекка, диләр.* А.Хәсәнов // Начар; мораль яктан түбән дәрәҗәдәге. *Синең таянычың шул казакларда. Ләкин бу таяныч черек.* Р.Батулла. *Диңгез аша Кайткан таштан күчермәләр, Килгән черек европалык, Рәсәйнең аңын буар ялагайлык, Тәти сарайлык.* Ф.Яхин

**2.** *и. мәгъ.* 1) Черегән әйбер. --- *монда үскән кыргый җиләк җирдә килеш чери; юеш черек исе килә...* А.Тимергалин. *Ә төбендә исә агачның ярты юанлыгында диярлек бер урынын черек алган, кеше кереп утырырлык бик уңайлы куыш хасил булган.* Р.Фәизов

2) Авырудан таркалган нәрсә; бозык бүлендек. *Мин сап-сары, коры сөяк инде, Шул көрәшләр төенен тик санап, Үпкә черекләрен төкерә-төкерә, Караватта ятам, сызгалап.* М.Җәлил

◊ **Чере́к көле** *к.* **черек оны**. *Аңа болай дип җавап биргәннәр: «Һәрбер таштан тузанын сыпырып төшер һәм битеңне куй, хәтта черек көле дә мәхәббәтнең хуш исен юкка чыгара алмый».* Р.Вәлиев. **Чере́к оны** Черегән агачтан калган коры онсыман масса

**ЧЕРЕ́К АВЫРУЫ** *и. биол.* 1) Агачларның үзагачын, үсемлекләрне черетә торган авыру. *Горчица зарарлы бөҗәкләрдән, гөмбә, черек авыруларыннан, чүптән арындыра, туфракны кабарта.* Шәһри Казан. *Агачны исә черек авыруларына каршы 6–7 процентлы мочевина, ягъни карбамид (10 литр суга 650 грамм исәбеннән) белән сиптереп эшкәртергә була.* Хезмәт даны

2) Умарта корты курчакларының үлеменә китерә торган авыру; *русчасы:* **гнилец**. *Үлгән личинкалар тоташ череп таркала торган йогышлы авыруны корт үрчемнәрендәге черек авыруы дип атыйлар.* Умартачылык

**ЧЕРЕККУЛ** *и. мыск.* Әйберне еш кына төшереп җибәрүчән, тотып өлгермәүче кеше

**ЧЕРЕКЛЕК** *и.* 1) Черек булу, черегән булу. *Черек помидорның черeклегендә дә объектив сәбәпләр бар.* Р.Батулла

2) *күч.* Бозыклык, әхлаксызлык, таркалыш. *Бозыклык, фәхешлек үзәге, әхлакый черeклек оясы – зур шәһәр аның өчен түгел иде.* Т.Галиуллин. *Әсәрнең төп идеясе – акчаның кешеләр тормышында хакими роль уйнавын һәм шушы шартларда кешеләрнең теләсә нинди бозыклыкларга, түбәнлекләргә бара алуын, гомумән, акча хакимлек иткән җәмгыятьнең черeклеген күрсәтү.* К.Гыйззәтов

**ЧЕРЕ́К-МЕРЕК** *и.* **1.** *к.* **черек-чарык 1**. *Бусы үзләренә, безгә дигәне лапаста – черек-мерекләрен шунда ташлаганнар.* Ш.Галиев

**2.** *к.* **черек-чарык 2**. *Малай базның бер почмагында --- черек-мерек такта башлары өелгән бер кучкә тап булды.* В.Нуриев

**ЧЕРЕКМИ** *и. мыск.* Хәтерсез кеше. *Төрек баеның кызыннан да баш тартканымны әйтеп тормадым, ул черекми барыбер аңламас.* Н.Әхмәдиев. *Әнә шулай гаҗәпкә калып торганда, киткән җиреннән ут капкандай йөгерә-атлый Азалия кайтып керде: – Черекми, иң кирәк әйберемне оныткамын, – дип, үзен үзе әрли-әрли, кубрикка төшеп китте.* С.Сабиров

**ЧЕРЕКТЕЛ** *и. мыск.* Усал, ямьсез телле кеше. *Черектел! Бер генә дә юньле сүз ишетеп булмады үзеңнән...*

**ЧЕРЕ́К-ЧАРЫК** *и. җый.* **1.** Черегән агач кисәкләре. *Бөтен җирдә черек-чарык та коры ботаклар гына!* Р.Вәлиев

**2.** *с. мәгъ.* Черегән, черек. *Чөнки алар да, Исхакның үзе кебек үк, черек-чарык бүрәнәләреннән җил өреп торган тәбәнәк түшәмле Мәллә мәктәбендә генә укырлар...* А.Гыйләҗев

**ЧЕРЕЛДӘВЕК** I *с.* **1.** 1) Ачы нечкә (тавыш тур); чер-чер килә торган. *Иптәш егетләре кайсы кая таралгалап беттеләр, рус егетләре, кызларын култыклап, болынга таба юнәлделәр, берсе двухрядкасын гөрләтеп җибәрде, черелдәвек ачы тавыш белән берсе такмаклый башлады ---.* М.Мәһдиев

2) Черелдәү гадәте булган; елак (кеше тур.).

**2.** *и. мәгъ.* Черелдәү гадәте булган, гел черелдәүче кеше; елак

**ЧЕРЕЛДӘВЕК** II *и. зоол.* Черелдәвекчәләр семьялыгыннан чер-чер иткән сыманрак тавышлы, башында бүреге булган җирән төстәге кечкенә генә урман кошы; сызгырак чыпчык; *русчасы:* **свиристель**

**ЧЕРЕЛДӘВЕ́КЧӘЛӘР** *и. күпл. зоол.* Чыпчыксыманнар отрядыннан сыерчыкка охшаш куе мамыклы, кыска койрыклы, тар канатлы, бүрекле черелдәвекләрне һәм ефәк черелдәвекләрне берләштергән семьялык

**ЧЕРЕЛДӘТҮ** *ф.* 1) *йокл. юн. к.* **черелдәү**. *Дөрес ул, тик чикерткәләрне дә кирәгенчә черелдәтә белергә кирәк.* Ф.Сафин

2) *сөйл.* Ачы нечкә тавыш белән сызгырту. – *Кайсыгыз җиңә – машина шуңа булачак, – дигәч, сыбызгысын черелдәтеп, көрәшергә сигнал бирде.* Ф.Садриев

**Черелдәтә башлау** Черелдәтергә тотыну

**Черелдәтә тору** Әлегә черелдәтү; бернигә карамый черелдәтү. *Ә үзе, бик җаваплы эш башкаргандай үтә җитдилек белән, баягы кебек үк чебешләрне күтәрә, җилпендерә, черелдәтә тора һәм зур ихласлык белән түшләренә теге чыбыклар белән я кызыл, я зәңгәр буяулар төртә тора.* Ф.Баттал

**Черелдәтеп алу** Тиз генә черелдәтү

**Черелдәтеп кую** Бер тапкыр черелдәтү

**Черелдәтеп тору** Әледән-әле черелдәтү; әле, хәзер черелдәтү

**ЧЕРЕЛДӘ́Ү** *ф.* 1) Кайбер кошлар, бөҗәкләр бик нечкә авазлар чыгару. *Һәр тарафта күзгә күренмәс чикерткәләр черелди, кызыл чалмалы шайтан таягы өстендә бер өер черки тирбәлә, сизгер усак яфраклары талгын җилдә шыбырдаша.* А.Тимергалин. *Якында гына үскән куакларда кошлар черелди.* И.Хуҗин

2) Кайбер механизмнар, җайланмалар нечкә тавыш чыгару. *Черелдәп телефон шылтырауга, Хәтимә, кулындагы теге эшен ташлап, түр бүлмәгә йөгерде.* Ш.Бикчурин. *Тик милиционер, сыбызгысы черелдәп, туктарга мәҗбүр итә.* Н.Әхмәдиев

3) Ачы, нечкә тавыш белән кычкыру яки сөйләү. *Задатка акчамны сорый башлагач, теге ике марҗа, задатканы кайтармау юлында булырга кирәк, шулкадәр колак төбемдә черелдәп кычкырырга тотындылар.* Г.Тукай. *Ә-ә, шулаймы? Би-ик шәп, би-ик яхшы, дип черелдәде хатыны.* Д.Гыйсметдин

**Черелдәп җибәрү** Көтмәгәндә черелдәү. *Указны да җәлт кенә тартып чыгарды һәм, аңа күз салып алуга ук, астына ут капкандай черелдәп җибәрде ---.* Ф.Баттал

**Черелдәп кую** Бер тапкыр черелдәү

**Черелдәп тору** Даими, әледән-әле черелдәү; әле, хәзер черелдәү. *Ялгышмасам, француз язучысы, бакчада бер сандугач сайрасын өчен, йөз чикерткә черелдәп торырга тиеш, дигән, имеш.* Ф.Сафин. *Чикерткәләр черелдәп торачак, кырмыскалар йөгереп йөреячәк, агач башларыннан, койрыкларын ботакка урап, елмайган-ыржайган маймыллар асылынып торачак, басуларда ел саен өч-дүрт мәртәбә игеннәр өлгерәчәк.* Безнең гәҗит

**Черелди башлау** Черелдәргә тотыну. *Элгәре алай булмаган бугай, бу елларда инде, берәүгә башкода җибәрсәң, кызның атасы мәһәр ягын кайгыртса, анасы, кайнишле җир түгелме, кайнанасы усал түгелме, дип черелди башлый.* Г.Ибраһимов. *Хатын-кыз черелди башлый.* Т.Миңнуллин

**Черелди бирү** Бернигә карамый черелдәү

**ЧЕРЕМ** *и.* Аз (кыска) вакытлы йокы; ярым йокы хәле. *Аннары шагыйрь өстәл өстендә ике кулын мендәр итеп черемгә китә.* Г.Гомәр. *[Абзый] --- бераз черем итим дип, зур якка чыгып, диванга ятты. Ләкин череме булмады.* Л.-Х. Таналин

**ЧЕРЕМӘ** *и.* **1.** 1) Туфракның үсемлек яки хайван калдыклары череп таркалудан барлыкка килгән состав өлеше; *русчасы:* **перегной**. *Агач төпләрен йомшартып, черемә салыгыз.* Ф.Садриев. *Үсемлек һәм хайваннар калдыгыннан микроорганизмнар һәм башка шартлар катнашлыгы белән хасил булган черемә инде туфракның иң кирәкле, иң файдалы өлеше булып тора.* Җир һәм туфрак

2) Шундый өлеш һәм туфрак катнашмасыннан торган органик ашлама; *русчасы:* **компост**. *Җирне алдан казырга һәм черемә белән ашларга кирәк.* Акчарлак

**2.** *с. мәгъ.* Составында шундый өлешләрнең берсе булган, шундый өлештән ясалган. *Хәтерегездәдер, бер вакыт торф, черемә чүлмәкләре белән ничек ду кубып йөрделәр?* М.Зарипов

**ЧЕРЕ́М ИТҮ** *ф.* Кыска гына вакыт җиңелчә йоклап алу. *Күп тә черем итмәдем төсле, кисәктән генә уянып киттем.* А.Хәсәнов. *Нәнәй бәләкәй яктагы түшәгенә ятып черем итә.* Д.Булатова

**ЧЕРЕПИ́ЦА** *и. рус к.* **чирәп**. *Аннары тагын шунысына игътибар итте Миңнулла: авыл өйләренең түбәләре күбесенеке йә калай, йә черепица яки такта белән ябылган, бер генә салам түбә дә юк.* В.Нуруллин. *Менә түбә ябарга черепица цехы ачарга җыенабыз.* Ф.Яруллин. *Түшеңдә черепица түбә күрү – кайгыдыр, ди Мөхетдин бине Гарәби.* Ф.Яхин

**ЧЕРЕТЕП** *рәв. сөйл.* Бик нык; гадәттән тыш. *Черетеп макта! Чыдам диген, нык диген!* Н.Гыйматдинова. *Дөнья хәлләрен сөйләшеп, тирә-юньне черетеп сүгеп, Марста тереклек бармы-юкмы дип, тагын кайда утырасың инде, мунчада утырмыйча.* Шәһри Казан

**ЧЕРЕТКЕЧ** *с.* Черетә торган, черүгә китерә торган. *Сырганак мае – ялкынсынуга каршы бик шәп чара, череткеч бактерияләргә дә көн күрсәтми, тәнебездәге йомшак тукымаларны төзәтү, үз хәленә кайтару үзлегенә ия.* Безнең гәҗит

**ЧЕРЕТҮ** *ф.* 1) Берәр нәрсәнең черүенә юл кую, черек хәлгә китерү. *Басудагы салам-печәнен, фермасына ташырга да хәленнән килмичә, җир өстендә черетсә черетә, ләкин колхозчысына бирми.* З.Хөснияр. – *Ал туннарны, асыл кеш, җофар тиреләрен урманда черетәсем килми, – диде Күксә.* Л.Зөлкарнәй

2) *күч.* Авыр шартларга куеп, авыр шартлар барлыкка китереп, берәр әгъзага, сәламәтлеккә зарар китерү. *Ул гыйлем кешенең күкрәген черетә, кулларын нечкәртә, имеш.* Г.Тукай. *ТЭЦта гына гаеп түгел, тимерьюл гына да зыян салмый, силикат кирпеч заводы черетә адәм балаларын!* А.Гыйләҗев. *Ашамыйча эчү гадәте әтисенең бавырын, бөерен череткән, соңрак йөрәге тоткан.* Т.Галиуллин

3) *күч.* Авыр, түзә алмаслык шартларда озак тоту, шундый шартларда һәлакәткә дучар итү. *Зур кызларын, бик байга бирәбез дип, күп кайнишле йортта череткәннәр иде, инде бусын ялгызрак җиргә бирергә исәпли, ди.* Г.Ибраһимов. *Менә сезнең ишеләр мине унсигез ел сөргендә череттеләр.* Г.Әпсәләмов. *Нишләп әле мин гөнаһсыз башымны ташкапчыкта черетергә тиеш?!* В.Нуриев

4) *күч.* Какшату; юкка чыгару. *Наркоманнар, эчкечеләр Черетәләр милләтнең нигезен.* В.Гали

5) *күч.* Вакытны, гомерне бушка әрәм итү. *Житәр, Кәүкәбелҗәннәт аның белән күп черетте гомерен.* Ф.Садриев

6) *күч.* Бик хурлау; гайбәтен сату. *Я, егетләрнең данын черетеп, балалар шикелле юк-барга тәмсез булмагыз әле.* Г.Бәширов

**Черетә бару** Тоташтан черетү; торган саен күбрәк черетү. *Яман чир үпкәсе белән бугазын черетә барганда, ул, соңгы атын, затлы кылычын, йөзек-балдакларын сатып, кое казытты.* Р.Батулла

**Черетә башлау** Черетергә тотыну. *Ярый ла барысы да уң гына барса, яңгыры явып китеп, печәнне юешләтеп черетә башламаса?* Ф.Яруллин. *Бу үтергеч атом калдыкларының тиздән аларның тәннәрен черетә башлаячагын, сөякләрен җимерәсен, каннарын агулыйсын башларына да китермиләр.* Ф.Бәйрәмова

**Черетә бирү** Бернигә карамый черетү. *Ләкин ул складларны, беркем дә ача алмаслык итеп, зур йозаклар белән бикләгәннәр дә икмәкне шунда черетә бирәләр.* А.Алиш

**Черетә килү** Әлегә кадәр черетү

**Черетә төшү** Бераз черетү

**Черетеп бетерү** Тулысынча черетү; барысын да черетү. *--- хәзер дүрт айдан бирле яуган яңгыр булган кадәресен дә черетеп бетерә.* Г.Бәширов. *Имеш, бу китапханәдә чын китапларның кадере юк, имеш, монда заманында гарәп язуындагы бөтен китапларны пыран-заран китереп, таратып, черетеп бетергәннәр ---.* Р.Вәлиев

**Черетеп килү** Акрын гына черетү. *Инде менә шул пуля минем үпкәләремне черетеп килә.* Г.Кутуй

**Черетеп ташлау** Көтмәгәндә бик нык черетү. *Син бигрәк инде, Кадернисаттәйне черетеп ташладың.* Т.Гыйззәт

**Черетеп тору** Даими черетү; әле, хәзер черетү

**Черетеп утыру** *сөйл. к.* **черетеп тору**

**Черетеп яту** *ф. сөйл. к.* **черетеп тору**. *Без юк-бар белән баш катырып, гомер черетеп ятабыз, әйтерсең яңарак берәр нәрсә уйлап табарга безнең башыбыз җитми.* М.Зарипов

**ЧЕРИ́К-ЧЕРИК** *иярт.* Нечкә генә чыркылдау тавышларын белдерә. *Көлештеләр. Рәмзи, печән учлап, Аткан булды шунда кызларга. «Черик-черик! Эх сез, өйрәтермен, Посып, шулай сүзне тыңларга!»* Ш.Мөдәррис

**ЧЕ́Р ИТҮ** *ф.* Еларга яки кычкырырга гына тору. *Чебен тимәс чер итәр.* Әйтем. *Шулай дип, баскычтан өй түбәсенә күтәрелсә, Зәйни малай шунда качкан икән, ул атасының ярым шашкан күз карашыннан чер итеп кычкырып җибәрде.* Г.Ибраһимов

**ЧЕРИ́-ЧЕРИ** *иярт.* Нечкә ачы тавыш белән кычкыруны, кычкырып сөйләшүне белдерә. *Чери-чери кычкырып, бер Пионер-Петрушка ишек башына килеп чыкты.* М.Җәлил

**ЧЕРИ́-ЧЕРИ ИТҮ** *ф.* Нечкә ачы тавыш белән кычкыру, кычкырып сөйләшү

**ЧЕРИ́-ЧЕРИ КИЛҮ** *ф. к.* **чери-чери итү**

**ЧЕРКӘМ** *с. диал.* Булдыклы, тәвәккәл, үткен

**ЧЕРКЕЛДӘ́Ү** *ф.* Нечкә өзек-өзек тавышлар чыгару, чер-чер итү. *Чырчу килеп, төрле кошлар, чикерткәләр черкелди.* С.Сабиров. *Әби дә черкелдәп көлде.* Н.Дәүли

**Черкелдәп алу** Аз гына черкелдәү. *Нәкъ шул мәлне бер кошчык черкелдәп ала.* Р.Юсупова

**Черкелдәп кую** Бер тапкыр черкелдәү. *Хафизов, кайдадыр, мич астындагы ярыкта сирәк черкелдәп куйган чикерткә тавышын тыңлый-тыңлый, --- хатирәләргә чумды.* Г.Кашапов

**Черкелдәп тору** Даими черкелдәү; әле, хәзер черкелдәү

**Черкелди башлау** Черкелдәргә тотыну. *Куаклыкта кыюсыз гына кошкорт черкелди башлады.* С.Сабиров

**Черкелди тору** Һаман, бернигә карамый черкелдәү. *Ләкин, ач булмаса да, сайрау тавышы чыгармыйы, тып-тын гына черкелди дә тора ул.* Г.Хәсәнов

**ЧЕРКЕН** *с. фар. диал.* Чирканыч, күңел кайтаргыч; бозык. *Без ханнарыбызга черкен булмадык, име, Ихсан.* М.Хуҗин

**ЧЕРКЕНЛЕК** *и. диал.* Чирканыч булу, күңел кайтаргыч булу; бозыклык. *Ата торып, ул сөйләсә – черкенлеге.* Мәкаль

**ЧЕРКИ** *и.* Икеканатлылар отрядыннан озын борынлы кан эчүче вак бөҗәк; *русчасы:* **комар**. *Тынлыкны улактан су агуы, йокысыз бер черки безелдәве, балыкларның ара-тирә су чупылдатуы гына боза.* А.Тимергалин. *Быел черкиләр былтыргыга караганда биш тапкыр артыграк үрчеде.* А.Гыйләҗев

◊ **Черки булып керү** *к.* **чебен булып күзгә керү**. *Председательнең колагына черки булып кердем: ашыкмыйк, минәйтәм, бер-ике көн көтик, үлән бераз кабарсын.* А.Гыйләҗев. **Черки дә борынын тыкмас** Бик төгәл, җиренә җиткереп эшләү турында. *Кузьмич – тәҗрибәле мөдир, уңга-сулга киткәннәрне үзенә генә хас төгәллек белән тәртипкә китереп, черки дә борын тыкмаслык итә.* Н.Әхмәдиев. **Черкидән фил ясау** *к.* **чебеннән фил ясау**. *Черкидән фил ясап бәйләнергә яратасың инде.* Т.Галиуллин. **Черки тимәс чер итәр** *к.* **чебен тимәс чер итәр**. *– Тукта, нишлисең? Авырттырасың ич, тиле! – Бигрәк черки тимәс чер итәр!..* Ә.Еники. **Черки тешләгән кебек (кенә)** Сизелер-сизелмәс, бер дә авырттырмыйча. *Берни булмас, черки тешләгән кебек кенә.* Н.Фәттах. *Менә аның аркасы черки тешләгән кебек аз гына авырту сизде ---.* Р.Вәлиев

**ЧЕ́Р КИЛҮ** *ф. к.* **чер итү**. *Мин, дигән, тисә чебен – Чер килеп оран салганмын.* Ф.Яхин

**ЧЕРЛӘ́Ү** *ф.* Йомырка басканда, чебиләр чакырганда өзек-өзек тавышлар чыгару; чырлау, кыртлау (тавык тур.). *Югарыдан, өйалды белән өй арасындагы ачык тәрәзәдән, кытаклап һәм черләп тавык чыкты.* Ә.Баян. *Аннан инкубаторныкыларның сәер ягы да бар икән: йомыркасын теләсә кая салалар, черләмиләр, утырмыйлар, чеби чыгармыйлар.* Ф.Латыйфи

**ЧЕРТ** *иярт.* Чикләвек, көнбагыш кабыклары ярылганда, шырпы һ.б.ш. нечкә агач әйберләр сынганда, теш арасыннан төкергәндә, берәр приборның төймәсенә басканда барлыкка килгән тавышны белдерә. *--- үзләре җир идәнгә теш арасыннан гына черт тә черт төкеренгәләп куялар.* Ю.Бондарев. *Черт тә черт көнбагыш чиртеп, көнозын биләмдә йөрде.* Н.Гыйматдинова. *Ул, фотоаппаратын тартып чыгарып, черт тә черт, төрле яклап фотога төшерә башлады.* Р.Галиуллин

**ЧЕ́РТ ИТҮ** *ф.* 1) Черт сыман тавыш чыгару. *Ниһаять, ул сабакларны --- сул кулы белән өстән тотып, уң кулы белән астан черт итеп кенә сындыра башлады.* А.Хәлим. *Мөхәммәт шаккатып утырган арада, яңадан нәрсәдер черт итте.* З.Мәхмүди

2) *күч.* Бозылу, ватылу билгеләре күренү; авырту, авыру, картлыкка бирешү. *Ә машинага килгәндә, аның яше 15 елдан артса да, һаман әле бер җире дә черт итмәгән, сазлыкта да, карбуранда да үкертеп йөри.* Безнең гәҗит. *Төрле телеканалларда бик популяр медицина тапшырулары алып баручылары да гел кисәтеп тора: черт иткән саен табибка, диләр.* Безнең гәҗит

**ЧЕРТЛӘТҮ** *ф.* Черт-черт иттерү, черт иткән аваз барлыкка китерү. *Пистолетны чертләтеп, малайларны да куркыткан булдым, чыпчыкларга да төбәп атып карадым.* Р.Вәлиев. *Гөлфия, чертләтеп, күн сумкасының тимер биген ачты.* Н.Гыйматдинова. *Кулларына чертләтеп богау кидерәләр дә, һәллүк – тимер рәшәткәле тарафка алып китәләр.* Ватаным Татарстан

**Чертләтә башлау** Чертләтергә тотыну. *Азат, чистартылган почмакка метр таягы сузып салып, аппаратын чертләтә башлады.* С.Шәмси

**Чертләтеп алу** Тиз арада чертләтү. *Ул арада Хөрмәт берничә мәртәбә фотоаппаратын чертләтеп алды.* Р.Кәрами

**Чертләтеп бетерү** Тулысынча чертләтү. *Бөтен кассетасын чертләтеп бетергәч, Матушкин, күрше тауның зәңгәрсу җәрәхәтен төшерергә дип, төсле яңа тасма куярга уйлаган иде ---.* Ә.Мушинский

**Чертләтеп кую** Бер-ике тапкыр чертләтү. *Аннары, кулларын аркасына таба сузып, таратып салынган чәчләре арасыннан нидер эзләгәндәй итте – ике тапкыр эрбет чикләвен ваткан сыман чертләтеп куйды.* Р.Мөхәммәдиев

**Чертләтеп тору** Даими, еш чертләтү; күпмедер вакыт чертләтү; әле, хәзер чертләтү. *Хәзер менә ул парлашып көнбагыш чертләтеп торыр бу авыл малае белән.* К.Кара

**ЧЕРТЛӘ́Ү** *ф.* Шырпы сызганда, сынганда, көнбагыш ярганда, чикләвек чистартканда һ.б.ш. вакытта черт иткән тавыш барлыкка килү. *Тузлар көйрәде, чертләп яна башлады, ал бүлмәдә сыек яктылык тибрәнде.* Л.Зөлкарнәй. *Кинәт корыган агач ботаклары чертләде, һәм куе ешлыктан нәкъ Бибисара каршысына Талип килеп чыкты.* Н.Гыйматдинова. *Төнге яңгырның елак тавышын бүлеп, капка келәсе чертләп бикләнде.* А.Әхмәтгалиева

**Чертләп кую** Бер тапкыр чертләү. *– Мәгез әле, маладуж, – сумкасының биге чертләп куйды. – Гаратскуй күчтәнәч авыз итегез.* Җ.Рәхимов. *Менә мылтык сыны урталай бөгелде, җиңелчә чертләп куйды.* В.Имамов

**Чертләп тору** Өзлексез чертләү. *--- Мендельсон маршы яңгырады, матур теләкләр әйтелде, чәчәкләр бүләк ителде, котлау, тәбрик сүзләрен дә җәлләмәделәр, фотоаппарат та өзлексез чертләп торды.* Р.Кәрами

**ЧЕРТМӘН** *и. зоол.* Чертмәнчәләр семьялыгыннан агачтан ясалган өй җиһазларында яши, черт-черт сыманрак тавыш чыгара торган кечерәк коңгыз; *русчасы:* **точильщик**

**ЧЕРТМӘ́НЧӘЛӘР** *и. күпл. зоол.* Катыканатлылар отрядыннан үзагачны зарарлый торган зур булмаган коңгызлар семьялыгы

**ЧЕ́РТ-МЕРТ** *иярт.* Чыбык-чабык, утын янганда ишетелгән өзек-өзек яңгыравык һәм тонык тавышларны белдерә. *Түгәрәк баз авызыннан өй эченә бөркеп яктылык төште, анда югарыда җил искәне һәм, ишетелер-ишетелмәс черт-мерт килеп, майлы түмәрләр янганы ишетелде.* Н.Фәттах

**ЧЕ́РТ-ЧЕРТ** *иярт.* **1.** 1) Чикләвек, көнбагыш кабыклары ярылганда, нечкә агач әйберләр сынганда, төкергәндә, кайбер механизм төймәләренә баскаланганда һ.б.ш. барлыкка килгән өзек-өзек тавышны белдерә. *Машинкада черт-черт басып, ул бүлмә ишеге янында олырак кына бер хатын-кыз утыра иде.* В.Нуруллин. *Кулына җыйган чыбык кисәкләрен, черт-черт сындырып, учакка салды.* А.Хәсәнов. *Тынлыкны Ләйсәннең черт-черт көнбагыш яруы гына боза иде.* А.Гыймадиев

2) *к.* **чер-чер**. *Мич артында чикерткә тавышы килә: черт-черт*

**2.** *рәв. мәгъ.* Акрын гына һәм вак-вак атлап. *Көтүләр кайтып, сыерлар савылып, күрше кызлары кичке уенга чыгарга дип нәкъ көзге янында бөтерелгән вакытта, без, ике дус, кәҗә бәтиләре кебек черт-черт теркелди-теркелди, урман буена, каравылчы өенә таба юл тоттык.* З.Хөснияр. *– Авылда яшәп җәфаланамы соң инде шәһәрдәге җылы туалетны күргән, асфальтта биек үкчәле туфлиләр белән черт-черт итеп йөргән кеше, – дип сөйләнде авыл хатыннары.* Р.Газиз

**ЧЕ́РТ-ЧЕРТ ИТҮ** *ф.* Черт-черт килгән тавыш чыгару. *Тик мич ярыгында черт-черт итеп кычкырган чикерткә тавышы гына караңгы төн тынлыгын бераз боза иде.* К.Тинчурин. *Манатовның колагында черт-черт иткән тавышлар гына ишетелеп торды ---.* З.Хөснияр

**ЧЕ́РТ-ЧЕРТ КИЛҮ** *ф. к.* **черт-черт итү**. *Тиз арада арышлар черт-черт килеп табада сикерешергә тотындылар, һәр бөртеге зураеп, кызарып китте.* Ф.Яруллин. *Черт-черт килеп яна башлаган учак яктысында бу сәер дөнья тагын да ачылып, балкып китте ---.* Г.Гыйльманов. *Безнең тавык – ап-ак тавык, Йомшак тавык, бик сак тавык. Черт-черт килә, көйләп йөри, Әллә нәрсә сөйләп йөри.* Л.Шәех

**ЧЕРҮ** *ф.* 1) Микроорганизмнар тәэсиреннән органик матдәләр йомшарып таркалу. *Юешлектән иген, ашлык черидер ---.* Г.Тукай. *Кортласа, агач та чери ---.* В.Галиев // Тутыгу, эрозия яки башка химик процесслар тәэсирендә органик булмаган материаллар таркалу

2) Авырудан яки башка сәбәпле берәр әгъзага зарар килү. *Башкалар авырганда да бирешми килгән малай Зәйнинең уртлары чери, бөтен тешләре селкенеп төшә башлады, буй-буй чәче коелды.* Г.Ибраһимов. *Минем әти бит бу байларга кәвеш тегә иде, күкрәге черәп, кибеп үлде.* Г.Камал

3) *күч.* Җәфа чигеп гомер итү; авыр шартларда яшәп һәлак булу, юкка чыгу. *Әнә алар Себердә чери.* Г.Әпсәләмов. *Төрмәдә черисең киләме?* А.Гыйләҗев

4) *күч.* Әхлак ягыннан түбән төшү. *Кешелек рухи яктан чери башлады, аннан сасы ис килә башлады.* З.Хөснияр. *Койма түгел, вөҗдан чери бугай. Аны-сын булырмы төзәтеп?* Г.Сафин

◊ **Черегән бай** Бик бай кеше, күп байлык җыйган кеше. *Капиталистларның да черегән байлары яши бу йортларда.* Ф.Җамалетдинова. *Байның колы булганчы, этнең улы бул, дисәләр дә, кайчак шәһәрнең черегән байларына да кол булырга туры килә.* С.Поварисов. **Череп беткән бай** *к.* **черегән бай**. *Авылыбызда бик череп беткән бер кара бай бар иде.* Г.Ибраһимов. **Череп баю** Бик баю. *Тора-бара мин череп баедым.* З.Мәхмүди. *Менә берзаман череп баеп йөреп кайттылар болар.* А.Хәмзин. **Череп таркалу** Әхлак ягыннан түбән төшү, рухи таркалу. *Сез аксөяк, диярләр, безнең комсомоллар арасында андый мораль яктан череп таркалган кешеләр булмаска тиеш, диярләр.* Н.Фәттах. *– Син, – ди, – туган партиябезнең карарларын боза-боза, тәмам череп таркалгансың!* Г.Галиева. **Череп чыккан бай** *к.* **черегән бай**. *– Чыннан да, череп чыккан бай булган икән бу Апанаевлар, – диде тикшерүче, затлы әйберләргә исе китеп.* А.Тимергалин. *Тик бер нәрсәдән хәтта череп чыккан байлар да котыла алмый – әҗәлдән!* Д.Гыйсметдин

**Череп бару** Акрынлап черү. *Роллинг череп бара торган мәеткә охшады да калды.* А.Толстой. *Тәнемнең сызламаган җире юк, тере килеш череп барган кебек хис итәм үземне.* З.Мурсиев

**Череп бетү** Тулысынча черү. *Хәзер инде агачлар картаеп череп бетә язганнар, юл күптән җимерелгән, анда чокырлар барлыкка килеп, аларның күбесе су белән тулган иде.* И.Хуҗин. *Толып Фәләхетдиннең сараен сүткәндә, печәнлектән череп беткән затлы*

*келәмнәр, кар базыннан тутыгып тәмам эштән чыккан зур сәгать табыла.* А.Тимергалин

**Череп килү** Акрынлап чери башлау. *Инде ябылган йире дә череп килә.* Г.Ибраһимов

**Череп тору** Әле, хәзер черү; булган берсе черү. *Сез монда ни дип шул суык, салкын Сибириядә мөгаллимәлек итеп череп торасыз?!* Г.Исхакый. *Гомер бакый шулай инде, утыртып торасың, череп торалар.* З.Мурсиев

**Череп утыру** *сөйл. к.* **череп тору**. *Берничә көн үткәч, кемнеңдер башы эшләп, авыл читендәрәк череп утырган кеше тормаган бер өйнең эчен карагач, имәнеч бер күренешкә тап булганнар ---.* И.Хуҗин

**Череп яту** *сөйл. к.* **череп тору**. *Авыл уртасында әрәм булып череп ята торган Һашимов йортын колхоз правлениесенә бирдек.* А.Алиш. *Тымызык күлдә корт уйный – тышкы яктан тыныч һәм төзек күренсә дә, бу дөнья әкренләп эчтән череп ята шикелле.* А.Тимергалин

**Чери бару** Һаман черү, торган саен черү. *Диңгезче йөзәргә тиеш. Чери барган корабта, бухтада якорьда утырырга тиеш түгел.* Р.Закиров. *Ел саен чери барган катламны умырткасыз башка хайваннар файдалана һәм детрит – яр буе ләменең төп өлешен барлыкка китерә.* Биология

**Чери башлау** Черергә тотыну. *Кар астыннан чыккан чүп-чарны, чери башлаган яфракларны җыеп алганнан соң, бакча уртасындагы чирәмлек гүя битен югандай яшәренеп китте.* Г.Бәширов. *Әмма барыбер йортның инде иске икәнлеге, бүрәнәләрнең муртая, чери башлавы беренче карашка ук күренеп тора.* В.Имамов

**Чери бирү** Бернигә карамый черү. *Күпме хезмәт кертүемә карамастан, помидорлар чери бирә*

**Чери тору** Әлегә кадәр черү. *Аңарчы яшь гаилә булудан туктап, балаларыбыз үсеп бетә инде, күтәргән стена чери торыр – түбә ябарга ярамый, субсидияне көтәсе.* Татарстан яшьләре

**Чери төшү** Бераз черү. *Нигез бүрәнәләре чери төшкән булса кирәк, бер ягы белән сәҗдәгә китеп бара.* А.Шамов. *Вакытлар узудан табутның такталары гына чери төшкән.* Р.Сибат

**ЧЕРЧЕК** *с. диал.* 1) Кечкенә, ябык; чирләшкә. *Черчек чеби*

2) Вакчыл, бәйләнчек, үҗәт

◊ **Черчек чыгару** Кемне дә булса гаепләү, кимчелек табу, тавыш чыгару һ.б.ш. өчен сылтау эзләү. *Монда черчек чыгарылмый! Кемгәдер гаеп өю өчен, хәтта сылтау эзләү тиела.* М.Хуҗин. *Көн дә тавыш-гауга куптарасың, Сәбәпләре нидән, әйт, зинһар? Һәр нәрсәдән черчек чыгарасың, Дәшми көтәм, кайчан, дим, туктар.* К.Фатыйхова-Бәдретдинова. **Черчек эзләү** *к.* **черчек чыгару**. *Шундыйлар, илнең түренә басу өчен, бүтәннәрне гаепкә күмеп черчек эзлиләр, табалар сылтавын, диде.* М.Хуҗин. *Нинди генә милләт булсак та бит, Без – кешеләр! – шуны онытмыйк. Милләт арасында черчек эзләп, Нәфрәт дөньясына юлыкмыйк.* К.Фатыйхова-Бәдретдинова

**ЧЕРЧЕКЛӘНҮ** *ф. диал.* Вакланү, бәйләнү; дошманлану. – *Әйтерсең дөньяда рәтле кешеләр беткән, – дип, Харисовны алып килгәләве өчен, Шиапка бик черчекләнеп бәйләнгән иде.* Г.Толымбай

**ЧЕРЧЕКЛЕ** *с. диал.* Вак; четерекле, катлаулы. *Ул – аның өчен ирешә алмаслык кыен, артык черчекле бер нәрсә, ул – зур, тирән белем сорый торган авыр бер язу. Г.Алпаров*

**ЧЕ́Р-ЧЕР** *иярт.* Кошларның черкелдәвен, кайбер бөҗәкләрнең черелдәвен белдерә

**ЧЕ́Р-ЧЕР ИТҮ** *ф.* Чер-чер килгән тавышлар чыгару. *Орчык һаман күңелле итеп безелди, мич артындагы чикерткә чер-чер итеп тора.* И.Гази

**ЧЕ́Р-ЧЕР КИЛҮ** *ф. к.* **чер-чер итү**

**ЧЕРЧЕТ** *и.* 1) Төркиләр белән күп сугышкан маньчжур кабиләсе

2) *күч.* Дошман. *Лагерьларда черчетлар кайбер легионерларны кулга ала башлаган.* Г.Әпсәләмов

**ЧЕ́СТЬ БИРҮ** *ф. хәрби* Уң кулны чигә турына куеп, хәрбиләрчә сәламләү. *Вакытлыча урынына калган һәм пенсиягә ике айдан китәргә тиешле штаб башлыгы трибуна янына йөгереп килеп честь бирде.* И.Хуҗин. *Юлдагы инспекторлар да андыйларга честь биреп кенә калалар.*А. Хәмзин

**ЧЕСУЧА** *и. кыт.* **1.** Ефәкнең аерым бер сортыннан полотно ысулы белән тукылган саргылт төстәге тыгыз ефәк тукыма. *Чесучаны тәмам кибеп беткәч кенә, ә башкаларын ярымюеш килеш үтүкләргә.* Кәеф ничек?

**2.** *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән. *Шаһмар мирза, гадәттәгечә, иртә сәгать җидедә торып, киң чесуча пинҗәген тулы гәүдәсенә киеп, калын кызыл агач таягын тотып, үзенең сөекле карт эте Каракүз белән --- бакчага кереп китте.* К.Тинчурин. *Шартына махсус яхшы да, килешле дә булсын дип, ул өстенә кыек якалы бик иркен ефәк күлмәк һәм чесуча ак чалбар киде.* Ә.Еники

**ЧЕТЕК** *с.* Гадәттәгедән күпкә ешрак йомыла торган (күзләр тур.). *Бу чагында йокыдан уянган Абдул четек күзләрен угалый иде.* С.Рәфыйков

**ЧЕТЕРЕК** *с. сөйл. к.* **четерекле**. *[Апуш:] А-а, гаҗәп четерек икәнсең!* К.Тинчурин. --- *бер тапкыр Кафия бик четерек хәлгә эләккән.* И.Гази

**ЧЕТЕРЕКЛӘНҮ** *ф.* Четерекле булып китү. *Кыз белде: хәл четерекләнә.* К.Насыйри. *Шуңа күрә җинаятьчеләрне тоткарлау мәсьәләсе гаять четерекләнде.* Ш.Шәйдуллин

**Четерекләнә бару** Торган саен четерекләнү. *Тормыш итүләре исә торган саен катлаулана, четерекләнә барды.* М.Хәсәнов. *Глобализация, ассимилизация кызулана барган саен, хәл катлаулана, четерекләнә генә бара.* Р.Фәйзуллин

**Четерекләнеп калу** Ахырда четерекләнгән булу. *Кадрлар мәсьәләсе тагын да четерекләнеп калды.* Казан утлары

**Четерекләнеп китү** Кинәт четерекләнү. *Болай булгач, эшләр бөтенләй четерекләнеп китте бит әле.* Ш.Шәйдуллин

**ЧЕТЕРЕКЛЕ** *с.* **1.** 1) Бик вакчыл, педант; эш йөртү өчен авыр булган. *Ә ул үзе кайчан нишләргә икәнен төптән уйлап хәл итә, кирәк чакта четерекле дә, нәзберек тә була белә.* М.Маликова. *Әхәт абзый – бик четерекле кеше ул, юк-бар сорау биреп аптыратсаң, авызыннан бүтән келәшчә белән дә сүз тартып ала алмассың.* И.Диндаров

2) Саклык һәм төгәллек таләп итә торган. *Болай да четерекле эшне тагын да катлауландырып җибәрдем.* Р.Сәгъди. *Бик четерекле моментлар болар.* А.Хәсәнов

3) Катлаулы, буталчык, авыр. *Миңа андый четерекле йомышлар кушма, бозып куюым бар.* А.Гадел. *.Катлаулы, четерекле гомер юлы уза адәм баласы.* М.Хәбибуллин

**2.** *рәв. мәгъ.* Саклык һәм төгәллек белән. *Шуңа күрә бу мәсьәләләргә четерекле карарга кирәк.* С.Поварисов

**ЧЕТЕРЕКЛЕЛЕК** *и.* 1) Катлаулылык, буталчыклык

2) Берәр эшнең аерым детале, вак проблемасы. *Хәер, яшьләрне тормышның андый четереклелекләре әллә ни кызыксындырмый.* И.Хуҗин. *Тормышта мәшәкатьләр бетмәгән кебек, китап чыгару хезмәтенең дә үз четереклелекләре бетмәячәк.* М.Вәлиев

**ЧЕТЕ́РТ-ЧЕТЕРТ** *иярт. к.* **чытырт-чытырт**. *Күзләрен ачыр-ачмастан колак салды: четерт-четерт... черт-черт... четерт-четерт... черт-черт... Яна икән.* А.Хәлим

**ЧЕТЕ́РТ-ЧЕТЕРТ ИТҮ** *ф.* Четерт-четерт сыман тавыш чыгару. *Четерт-четерт итеп янган мич яктысында карточка карап утырган яралы егет берзаман ничектер сискәнеп китте ---.* Т.Нурмөхәммәтов

**ЧЕТЕ́РТ-ЧЕТЕРТ КИЛҮ** *ф. к.* **четерт-четерт итү**

**ЧЕТЕ́Р-ЧЕТЕР** *иярт. к.* **чытыр-чытыр**. *Үкчәләре ашалган ботинка табаннары астында алар четер-четер уалалар.* А.Гыйләҗев. *Әчем четер-четер янса да, мин сиздермим, көләмшаярам.* Н.Гыйматдинова

**ЧЕТЕ́Р-ЧЕТЕР ИТҮ** *ф.* Четер-четер килгән тавыш чыгару

**ЧЕТЕ́Р-ЧЕТЕР КИЛҮ** *ф. к.* **четер-четер итү**

**ЧЕ́Т-ЧЕТ** *иярт.* Күзләрне тиз-тиз ачып йомгалау рәвешен белдерә. *Әхтәм килгәч, карт күзлеген иплән кенә салып, шул кәгазь өстенә куйды да күзләрен чет-чет йомгалап алды.* Г.Әпсәләмов. – *Кирәкми, кирәкми!* – *диде* Эльвир, *күзләрен чет-чет йомып.* М.Маликова

**ЧЕХ** *и.* Чехиядә яшәгән, славян телләренең көнбатыш группасына караган телдә сөйләшкән төп халык һәм шул халыкның бер кешесе. *Алик һәрвакыттагыча пөхтә киенгән, өстендә өр-яңа джинсы костюм, аягында ялтыравыклы чех ботинкасы, юкарак чәчләрен бриолин белән ялтыратып тараган.* А.Гыйләҗев. *Бу сүз рус теленнән чех теленә дә кергән, охшаш сүз болгар теле диалектында да очрый ---.* А.Тимергалин

**ЧЕХОЛ** *и. рус* 1) Берәр әйберне бозылудан, пычранудан саклау яисә матурлык өчен өстеннән кидерелә торган махсус каплавыч; тышлык. *Аз-маз гына төшкән халык таралып бетте, һәм Клара, ак чехол кидергән чемоданын күтәреп, ялгыз калды.* Ә.Еники. *Дәһшәтле танкларның көпшәләренә авыр чехоллар киертелгән, бөтен платформаларда ниндидер бер шомлы тынлык хөкем сөрә иде.* М.Мәһдиев. *Камыт аяклы ефрейтор икенче катта, элекке начальник кабинетында, ишек-тәрәзәләрне ныклап ябып, штораларны төшереп, урындыклардан баррикада корып, ак чехоллы киң диванга урнаша.* А.Тимергалин

2) Үтәкүренмәле күлмәк эченнән кию өчен, тыгыз тукымадан тегелгән эчке күлмәк. *Уңайлы чехол алу*

3) Фуражканың җиңел материядән эшләнгән, алыштырыла торган өске өлеше. *Башка кигән ап-ак бескозырканың чехоллары гына күренеп калды.* Казан утлары

**ЧЕХОНЬ** *и. рус* 1) *зоол.* Кәлчәк. *Аска таба сузылган чыбыкка тотынып, яр буена ук төшәсең дә рәхәтләнеп балык тотасың: җәен, алабуга, судак, чехонь...* Сөембикә

2) Шул балыкның ашарга әзер ите. *Тел өстенә чеметеп кенә чехонь кыстырып, салкын сыра суырып бару – үзе бер гомер!* М.Галиев

**ЧЕ́ХЧА** *рәв.* **1.** 1) Чех телендә. --- *чехлар, чехча кычкырганны ишеттек, дип, ант итеп сөйләделәр.* Г.Әпсәләмов. *Итальянча, полякча, сербча, чехча укый.* Сөембикә

2) Чехлар кебек, шулар гадәтенчә. *Чехча фикерләү*

**2.** *с. мәгъ.* Чех телендә булган. *Чехча әсәр*

**3.** *и. мәгъ.* Чех теле. *Яхшы беләм латин телен, гарәп телен, Аңлый алам төрек телен, фарсы телен. Укый алам поляк, болгар телләрендә, чехча белән һәм шведча... венгр, румын ---.* Ш.Мөдәррис

**ЧЕЧЕН** *и.* Төньяк Кавказда, Чечен Республикасында яшәүче төп халык һәм шуның бер кешесе. *Ә балыкчылар арасында кемнәр генә юк: дагстанлылар, азәрбайҗан, әрмән, чечен, ингуш, нугай, кырым татарлары, үзбәкләргә кадәр күренә.* З.Мурсиев. *Тагын бездән шактый соң ачылган Төньяк Кавказ редакциясе бар иде, анда чечен, авар телләрендә тапшырулар ясала иде.* Р.Юныс

**ЧЕЧЕ́НЧА** *рәв.* **1.** 1) Чечен телендә. *Каршыга килүчеләр урысча һәм чеченча сөйләшәләр иде, араларында гарәпләр дә бар иде, ахры, алар да үз телләрендә кискен-кискен эндәшеп куялар.* Ф.Бәйрәмова. *Шуннан соң башкалардан өлкәнрәк булган Мөхәммәт Юркага чеченча нидер әйтте.* Р.Хисаметдинов

2) Чеченнар кебек, шулар гадәтенчә. *Танылган алып баручыга артык килограммнарын яндырырга кирәк булган, әлеге җыенда аны чеченча ябыгырга өйрәтәчәкләр.* Әлмәт таңнары. *Чеченча киенү*

**2.** *с. мәгъ.* Чечен телендә булган. *Чеченча язулар*

**3.** *и. мәгъ.* Чечен теле. *Чеченчаны белү*

**ЧЕЧЁТКА** *и. рус* Аяк табанын һәм үкчәсен идәнгә бәреп тыпырдаудан гыйбарәт ритмлы бию. *Казармада, ике урындык аркасына тотынып, яртышар сәгать чечётка тыпырдата идек.* Р.Кәрами. *Яраткан әбиләрен котлап, оныклары тамашачыларның көчле алкышлары астында заманча брейк, көнчыгыш, самбо, чечётка, чегән биюләрен башкардылар, шигырьләр сөйләделәр.* Авыл таңнары

**ЧЕ́ЧИЛ** *и.* Майсызландырылган сөттән ясала торган, җепселле, сузылучан, йомшак сыр төре. *Баксаң, чикләү кертелгән чечил сыры барыбер дә кибет киштәләренә менеп утырган ---.* Шәһри Казан

**ЧЕЧҮНЧӘ** *и. к.* **чесуча**. *Мохтарова юл киемнәрен алыштырырга өлгергән, өстенә ак чечүнчә костюмын киеп алган иде.* Г.Ахунов

**ЧЕ́ШИР** *и. ингл.* Англиядә Чешир графлыгында җитештерелә башлаган, тозлырак тәме кала торган каты сыр сорты

**ЧИ** I *с.* **1.** 1) Пешмәгән яки пешерелмәгән; кайнатылмаган (ашамлык тур.). *Өйдә абзыйлар, җиңгиләр шалкан кисеп кайткан булганга, шалкан ашарга утырдык; элгәре чи шалкан ашадык, аннан ары әни пешкән шалкан кертте.* Г.Исхакый. *Сез аны, ярышка әзерлибез дип, чи йомырка эчертеп кенә тоткансыз.* А.Хәсәнов // Пешеп җитмәгән. --- *Баязид ашарга бирелә торган чи икмәкләрдән шахмат фигуралары ясаган, ялгызы уйнар өчен, кесә кульяулыгын күмер белән сызгалап шакмаклаган иде.* Г.Ибраһимов. *Юлга чыгар алдыннан, һәр яралыга йөз иллешәр грамм спирт эчерделәр дә кечкенә чи ипи кисәге тоттырдылар ---.* З.Зәйнуллин

2) *сөйл.* Өлгереп, пешеп җитмәгән (җиләк-җимеш, яшелчә тур.). – *Йөземнәр чи, әле өлгермәгәннәр, пешмәгәннәр,* – *ди.* – *Бозарсың ашказаныңны, килешми әчкә анлар!* – *ди.* Г.Тукай. *Ә татар балалары шомырт, миләш шикелле җимешләрне чи, пешмәс борын агачларны сындыра-сындыра менеп ашап йөриләр.* Р.Зарипов // Кирәгеннән артык өлгереп картаймаган, сусыл һәм ашарга яраклы. *Чи кыярны даими*

*ашасаң, калкансыман биз белән авырып китү ихтималы кими.* Хезмәт даны

3) Коры булмаган, дымлы; кипмәгән. *Учак бераз төтенләп торды, чи чыбык башларыннан, чыж да чыж иттереп, салам юанлыгы гына төтен җепләре аттырды.* Г.Бәширов. *--- култыксага ябыша-ябыша, чи тары көлтәсе кебек авыр гәүдәсен өскә – җиденче катка сөйрәде.* А.Гыйләҗев. *Көлтә итеп кысылган чи яшел печән атлаган саен авырая, бау җилкәне кисеп керә башлый.* Н.Көбаш

4) Эшкәртелмәгән яисә беренче стадия эшкәртелүдән генә узган; яндырылмаган, киптерелмәгән, чистартылмаган; чимал хәлендәге. *Өйләрнең күбесе агачтан, бәгъзылары таштан, бәгъзысы чи кирпечтән салынмыш, бәгъзылары чыбыктан үреп, тышкы ягыннан балчык белән сыланмыштыр.* З.Һади. *Ходай биргән чишмә суын сөттән дә кыйммәткәрәк сата, ә чи нефтен бушлай читкә биреп җибәрә ---.* Р.Харис. *Берзаман магазиннарга кыздырылмаган чи кофе китереп тутырдылар.* Р.Гаязетдин // Куллануга әзер дәрәҗәгә җиткерелмәгән. *Болар төшереп алганнар, чөнки бер читтә исемлек буенча чи аракы сатыла (ирләр сүгенә-сүгенә эчәләр, дүрттән өч өлеше кое суы, диләр) – ирләр кәефле.* М.Мәһдиев. *Урыным Нифа янына туры килде. Чи аракы, су кушкан спирт булды. Нифа авызына да алмады.* Х.Камалов

5) Ачык; җөйләнмәгән; канап, кан саркып торган. *Башында исәпсез-хисапсыз уйлар буталган, йөрәге тулы сагыш, чи җәрәхәт, яра булган бу кешенең кая барасын берәү дә белми.* Н.Әхмәдиев. *Чи ярага вак тоз сибәм, дисең инде?* А.Гыйләҗев

6) *күч.* Коры, нигезсез. *Җиңеләймәсә, өй саен кереп, чи гайбәт сөйләп йөрмәс иде.* Г.Гыйльманов

7) *күч.* Тиешле дәрәҗәдә эшләнмәгән; сыйфаты түбән булган, эшкәртү таләп иткән (әсәр, аның теле тур.). *Әгәр терминологик сүзлектә дүртәр-бишәр синоним тезелеп китә икән, димәк, бу норматив сүзлек түгел әле, фәкать сүзлек өчен тупланган чи материаллар гына.* А.Тимергалин. *Сыйфаты кайтыш әсәрләр дә бер күз белән бәяләнә: чи хикәя, пешмәгән шигырь ягъни.* М.Хуҗин

8) Чын, берни кушылмаган, саф. *Ну, малай, чи мишәрсең икән!* И.Юзеев. *Һәм ул бик дөрес тә, монда татарның чын чи татарлары җыелган.* Р.Вәлиев. *Миңнән берәү – чын даһи, Башкалары – чи даһи. Татар булып туганыңа Гарьләнерсең, билләһи!* С.Әхмәтҗанова

9) Сөргәндә, чәчкәндә эшкәртелми калган. *Чи җирләр*

**2.** *рәв мәгъ.* 1) Бөтенләй, тулысынча; тоташ. *Монда Нугайдан үзләренең наданлыкларын белмәгән байтак кына мулла вә мөәзиннәр вә шуларның чи надан остабикәләре җыелганнар.* Г.Буби

2) Сөргәндә, чәчкәндә эшкәртелмичә калган, тиешле дәрәҗәдә эшкәртелмичә (җир тур.). *Коры аш ашаган көннәрдә кайбер печәнчеләрнең покосны я бик тар алып, яисә күрер күзгә киң алып та, астын чи калдырып чабуларына эчем пошып, кисәтү яса[дым] ---.* В.Нуруллин. *Елый-елый диярлек, чи калган урыннарга шуны сибеп чыктылар.* А.Гыйләҗев

◊ **Чиен чыгару** 1) Авыр эш белән интектерү; арытып бетерү. *Йорт салу мәшәкате аны ярым картайта, чиен чыгара, йокысыз калдыра, тамактан яздыра, бурычлы итә.* А.Гыйләҗев; 2) *диал.* Җиренә җиткереп эшләү. **Чи канга бату** Бик нык канау, җәрәхәтләнеп, кара канга бату. **Чи канга батыру** Бик тирән җәрәхәтләп, күп кан агызу, кара канга батыру. *Группа егетләрен чи канга батырып сугыштырып йөрде-йөрде дә техникумны да тәмамлап тормады.* А.Хәсәнов. **Чи чыгу** Авыр эш эшләп азаплану; озак, хәлдән тайганчы эшләү. *Ысулы саутия белән хәреф таныту җиңел булса да, ул ярым грамота, беренче адым гына; икенче адымга киткәч, аның чие чыга башлый: аңларга, аерырга, белеп эшләргә өйрәтү җитмәгән булып кала.* Г.Алпаров. *Аяклар бетте, абый, аяклар! Чие чыкты Казанда йөреп.* Х.Сарьян

**ЧИ** II *и. бот.* 1) Кыяклылар семьялыгыннан чәчәк төркеме җәелеп үскән, озын нечкә кыяклы күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* **чий**. *Күчмә кабиләләр үзләренә нәкъ менә чи үскән җирне сайлый торган булганнар.* Бөгелмә авазы. *Алар шул рәвешле, ягъни чи ботагына чорналган җеп белән үзләренең куышларын бизәп, тормышларына ямь өстәгәннәрдер, ят күздән сакланганнардыр, дип гөманларга гына кала.* Шәһри Казан

2) Шул үләннең яки камышның кипкән сабакларыннан үреп ясалган читән. *Өйдән чыккан кыз чидән тышкары.* Мәкаль

3) Шул үләнгә йон чорнап, чыпталар, келәмнәр үрү техникасы. *«Чи» дип аталган әлеге техникада эшләүче бөтен Россиягә бердәнбер оста Владимир Викторович.* Шәһри Казан

**ЧИАНУРИ** *и. груз. муз.* Грузин халкының 2–3 кыллы чиртеп уйный торган уен коралы

**ЧИБӘР** *с. монг.* **1.** 1) Тышкы кыяфәте матур, гүзәл булган (кеше тур.). *Беренче мәртәбә мин үземне кеше итеп, кыз кеше итеп һәм... чибәр, сылу кыз итеп тойдым!..* А.Гыйләҗев. *Егет төшеп калганнардан түгел шул – чибәр, төз гәүдәле, спортта аңа тиңнәр юк.* А.Гыймадиев

2) Тышкы кыяфәте күңелгә ятышлы, төсләрнең, форманың гармонияле булуы белән аерылып торган. *Минем йодрыкның иң ныгы әле яңа гына килеп катнашкан чибәр киемле, сары башлы малайга эләккән булырга кирәк ---.* Г.Ибраһимов. *Үзең дә, ичмаса, бер кеше төсле чибәр күлмәклек алып биргәнең дә юк.* Г.Камал // Рәхәт, матур. *Нәкъ бер елдан, шушындый матур язда, чибәр җылы кичтә кавышырсыз...* А.Гыйләҗев. *Хатыннар – дөнья анасы, Хатыннар – илгә терәк. Чибәр чак үтә дә китә, Акыллар көн дә кирәк.* Г.Афзал

3) Куелган таләпләргә туры килгән, сыйфатлы; яхшы. *Шуның өчен, анасы булмаса да, бик чибәр төшләрдән җаучы килеп һәм бик яхшы йиргә биргәннәр иде.* Г.Исхакый. *Элек-электән түрәләрне майлап-җайлап җиңел көн итәргә күнеккән чибәр тормышлы кешеләр хәзер дә җаен таптылар.* Г.Бәширов

4) *этн.* Туганнар, кардәшләрне берберсеннән аерып, ярату, үз итү, хөрмәт итүне белдереп атау өчен кулланыла торган сүз. *– Шәлеңне салып кына ишек төбенә бар, чибәр абыстаңа әйт! – диде.* Г.Исхакый. *Нихәл, чибәр апа, эчеңнән салкының чыгып беттеме инде?* А.Гыйләҗев. *Әтинең энесенең хатыны – «чибәр җиңги» (халык артисты Миңгол Галиевнең әнисе) – бик күркәм, безгә бик игътибарлы булып, безнең теләкләрне Наиләмнең әтиәнисенә дә җиткерде.* В.Галиев

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Күңелгә ятышлы, килешле итеп. *Кызның кыштан итәкле, килешле тегелгән зәңгәр күлмәге аның нечкәрәк, уртача зифа буен ничектер аеруча чибәр күрсәтеп тора.* Г.Ибраһимов

2) Яхшы; шәп; сыйфатлы итеп. *Шуннан берничә атналар буенча майлаган кебек йомшак, ал да гөл кебек чибәр йөри.* Г.Ибраһимов. *[Мостафа:] Зыков, Филатовлар да чибәр эшлиләр.* Г.Кутуй

**3.** *и. мәгъ.* 1) Матур кеше, гүзәл кеше. *О-о, егетләр, Кларадай чибәр белән опера карау – үзе бер театраль сәхифә ул.* А.Хәсәнов. *Имеш, үзе дөньяда бер чибәр, характеры белән ирләргә биргесез.* А.Гыйләҗев. *Күзгә күренеп үзгәрдең, ай саен яшәрәсең, син хәзер гүзәлләрнең гүзәле, янәшәңә куярдай бүтән чибәр җир йөзендә юктыр.* В.Имамов

2) *тарт. форм. ирк.* **чибәрем**. Гадәттә балаларга, хатын-кызга мөрәҗәгать итү сүзе. *Ах... җир җиләгем, кура җиләгем, Сагынып көтәм сине, чибәрем.* М.Җәлил. *Ю-ук, чибәрем! Мылтыгым булса да, мин кошларга тимим...* М.Хәсәнов

**ЧИБӘРЛӘНҮ** *ф.* 1) Матурланып китү, элеккедән матурракка әйләнү. *Ансыз да асыл сөяк булган Алмачуарым бу арада карап туйгысыз булып чибәрләнде.* Г.Ибраһимов. *Ул шуларны уйлады һәм Розаның: «Матур тормышта, сөеклем, ямьсез кеше дә чибәрләнә», – диюен хәтерләп елмайды.* Г.Кутуй

2) Бизәнү-ясану. *Бар да ясанган, чибәрләнергә тырышкан.* Г.Ибраһимов. *Чибәрләнеп чәчтараштан чыкканда, поезд инде күздән югалган була.* Р.Батулла

**Чибәрләнә бару** Торган саен чибәрләнү. *Күргән саен чибәрләнә генә барасыз.* Г.Әпсәләмов. *Күрше, ни гаҗәп, син һаман чибәрләнә генә барасың, күзем тимәсен!* Г.Галиева

**Чибәрләнә башлау** Чибәрләнергә тотыну. *Язның соңгы ае – табигатьнең, пычраклардан арынып, яшел кием белән чибәрләнә башлаган чагы.* С.Поварисов

**Чибәрләнә төшү** Бераз чибәрләнү; тагын да чибәрләнү. – *Сез тазаргансыз! Чибәрләнә төшкәнсез, – дип, гади мактау сүзләрен әйтеп, аның кулын кысты, килә алмый йөрүенә гафу үтенде.* Г.Ибраһимов. *Эльза тагын да чибәрләнә төшкәндәй тоелды Гарифка.* А.Гыймадиев

**Чибәрләнә тору** Әлегә чибәрләнү. *Син әле үсә, тагын да чибәрләнә тор, мин сине эзләп табармын, бу йөзегеңне югалтма, башкаларга бирмә, миңа дип сакла, ди бу.* Р.Рахман

**Чибәрләнеп алу** Тиз генә чибәрләнү. *Шул арада бераз чибәрләнеп алырга да ниятли: битен катыкка буяп куя.* Безнең гәҗит

**Чибәрләнеп бару** Торган саен чибәрләнү; торган саен чибәррәк булып күренү. *Шулай да бу – яңа дөньяның һәм кешеләрнең матурлыгын күрергә, «чибәрләнеп бара кызлар, яхшыра бара еллар» дип җырларга комачауламый ---.* Р.Мостафин

**Чибәрләнеп килү** Соңгы арада чибәрләнүе ныграк күренү, сизелү. *Сәламәтлегем бер рәвештә чибәрләнеп киләдер, ягъни бераз аякка басып йөри башладым инде ---.* Х.Хәсәнов. – *И аның ыспайланып, чибәрләнеп килүләре! – диде ул, гаебен аклагандай.* Н.Гыйматдинова

**Чибәрләнеп китү** Соңгы арада чибәрләнү. *Соңгы елларда гына чибәрләнеп китте ул.* В.Нуруллин

**Чибәрләнеп тору** Әле, хәзер чибәрләнү. *Батып барган кояш нурларында кызның болай да сөйкемле йөзе тагын да алсуланып, тагын да чибәрләнеп тора.* Ф.Абдуллин

**ЧИБӘРЛӘҮ** *ф.* Матурлау, бизәү. *Әлбәттә, буяп, бизәп, чибәрләп, йорттагы каралтыларның да адәм күзенә чалынырлык булганын мөмкин кадәрле зур, мөмтаз, менә диярлек ясый.* Г.Ибраһимов. *Чәч алучы мөлаем кыз, егетне чибәрләп, хушбуй сибеп, тагын килүенә өмет итеп, елмаеп озатып калды.* Р.Кәрами

**ЧИБӘРЛЕК** *и.* Матурлык, гүзәллек, чибәр булу. *Икесе дә чибәр чибәрлеккә.* В.Нуруллин. *Абый, аның чибәрлеге шундый, менә ни... э-э-э, кояш яктыртуы кебек нур сибә.* А.Гадел

**ЧИГӘ** *и.* 1) *анат.* Башның маңгай белән колак арасындагы өлеше. *Баш авырта, әйтерсең ике чигәгә кечкенә чүкечләр белән бертуктаусыз бәреп торалар.* А.Алиш. *Подъезд ишегеннән чыгуга, әтием, минем чигәмнән үбеп, хушлашырга ашыкты ---.* А.Әхмәтгалиева

2) Шул өлештәге чәчләр. *Чигәләр чаларды, нишлисең, ә үзем сәламәт.* А.Гыйләҗев. *Иртәнге җил, аның чигәләре агара төшкән саргылт чәчен бер якка сибеп, баш түбәсендәге пеләшен шәрәләндерде.* А.Вергазов

◊ **Чигә чәчен агарту** Күп газап күрү. *Ул бит синең аркада педсоветларда күпме таяк ашаган, синең өлгереш өчен күпме чигә чәчләрен агарткан, өйгә синең икеле капчыгыннан чак кына кайтыш дәфтәрләреңне интегеп ташыган, төннәрен йокламаган кеше.* Ялкын

**ЧИГӘ́ САКАЛЫ** *и.* Ирләрнең яңак буйлап, чигәдән иякә таба үстерелгән сакалы; бакенбард. *Ниһаять, хөкем йортының авыр ишеге шапылдап ачылды да, бусагада агара башлаган тузгак чәчле, чигә сакаллы, өстенә җиң очлары зәңгәр кәйтән белән каелган, керле, иске мундир кигән бер кеше күренде.* М.Галәү. *Ул «хатыны» дигән кешегә борылып карады, аның куерып кушылган кашлары хәрәкәтләнделәр, аз гына бөдрәләнеп торган ап-ак чигә сакаллары ут капкан кебек сыек зәңгәр төтен белән капланды.* А.Гыйләҗев

**ЧИГӘ́ЧӨЙ** *и.* Арба күчәрләренең баш-башларындагы тишеккә кертеп куелган чөйләр; чәкүшкә. *Ул арада чигәчөй кагып куярга да өлгерде.* З.Мәхмүди

**ЧИГЕЛДӘК** *и. диал.* Бавырсак. *Чигелдәк (вак бавырсаклар) сибеп җибәрә, оланнар узыша-узыша җыялар.* Сөембикә

**ЧИГЕНДЕРҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **чигенү**. *Апак, атны чигендер әле, мин арба башын кендегенә утыртам.* К.Кәримов. *Әрсезләнеп бозавына ияргән сыерны көч-хәл белән чигендереп, абзар капкасын япты.* М.Кәбиров // Борылмыйча гына арт белән артка күчерү. *Шофёр, машинасын чигендереп, кабат олы юлга чыга.* А.Тимергалин

2) Дошманга һөҗүм итеп, аны артка таба китәргә, качарга мәҗбүр итү. *Бәҗәнәкләрне һәм төрекләрне чигендереп, кыпчаклар XI йөз башында Идел аръягын һәм, озак та үтми, Идел белән Дон арасын басып алганнар.* Р.Фәхретдинов. *Атлы гаскәр юртавылны кырыклап чигендерде, олы гаскәр белән юртавылны бергә Болак күперенә куганда, Иван ярдәмгә Юрий Шемякин белән Фёдор Троекуров җитәкчелегендәге ике бүлемне җибәрде.* Р.Батулла

3) *күч.* Баштагы карарын, уй-фикерләрен үзгәрттерү, баш тартырга мәҗбүр итү. *Әмма язмыш мине вәгъдәмнән чигендереп, аларны бу юлы да Сак белән Сок хәлендә калдырып моңландырырга теләде, күрәсең.* Т.Әйди. *Ибраһим бәк ярсый-ярсый сүзгә керешкән иде дә, мәчет имамнары аны бик тиз чигендерде ---.* В.Имамов. *Мәгънәле сүз мәгънәсез гамәлдән чигендерә ала, әмма, мәгънәсезлектән котылу өчен, сүз генә җитми...* М.Мирза

**Чигендерә бару** Булган берсен рәттән чигендерү. *Бу аязлык арта бара, кояштан сузылган меңләгән утлы кылычлар җир өстен томалап торган соры шәүләләргә һөҗүм итәләр һәм аларны чигендерә баралар иде.* С.Рафиков

**Чигендерә башлау** Чигендерергә тотыну. *Филләрен йөгертеп, Аксак Тимер явы, Үргәнеч гаскәрләрен чигендерә башлап, изә-сыта килә иде.* Ф.Яхин. *1943 нче елның гыйнвар башында аларның дивизиясе Дон тирәсендә дошманны чигендерә башлый.* Казан утлары

**Чигендерә төшү** Бераз чигендерү; тагын да чигендерү

**Чигендереп кую** Көтмәгәндә чигендерү. *Бу тишек борын я уйлаган ниятеңнән кире чигендереп куяр.* Р.Гаязетдин

**Чигендереп тору** Вакытлыча чигендерү; хәзер чигендерү. – *Бәлки, эзе торып калгандыр, тапталмасын!.. – дип, кешеләрне читкә чигендереп тора иде.* Х.Сарьян. – *Чиратны тагын бераз вакытка чигендереп торабызмы? – дип текәлде [Габделбәр].* Э.Касыймов

**ЧИГЕНЕШ** *и.* 1) Артка таба хәрәкәт итү. *Димәк, эксперимент вакытында үзенә бертөрле вакыт чигенеше булганга охшый.* А.Тимергалин. *Иномарка, зур тизлектә тукталып, артка чигенеш ясады – тизлеге сәгатенә 90 чакрым иде.* Н.Акмал

2) Дошман кысрыклавы нәтиҗәсендә тоткан позицияне калдырып артка китү. *Чиста ятак, чибәр кызлар... Курорт инде перәме. Әйтерсең лә чигенешләр, Чолганышлар булмаган.* И.Гыйләҗев

3) *әд.* Язучының язу ысулы буларак, төп темадан читкә чыгу, икенче күренешне сурәтләп алу алымы. *Аның афишаны һәм ремаркаларны киңәйтеп, вакыйгалар һәм геройлар турында үз сүзләрен кертүен, үз бәяләрен бирә баруын лирик чигенешләр дип атарга була.* А.Әхмәдуллин. *Билгеле инде, чигенешләр сюжет динамикасын туктатып торалар.* Ф.Хатипов

4) *махс.* Диңгез суының периодик рәвештә кайту, чигенү күренеше. --- *ай тулганда яки яңа ай туар алдыннан, диңгез күтәрелешләре һәм чигенешләре куәтлерәк булган ---.* А.Тимергалин

5) *күч.* Билгеле бер фикердән кире кайту, кире уйлау. *Аның шушы олы йөрәкле кешеләр алдында баш июе һәм бу чигенешнең җиңел генә бирелмәве дә чагылырга тиеш портретта.* М.Маликова

6) *күч.* Үсештә артка китү күренеше. *Бер дөрләсәң, бер үрләсәң әгәр, Мәңге булмас артка чигенеш.* Л.Шәех. *Акчура милли көчләрнең чигенеш сәбәпләрен тикшерә һәм милли идеянең алгарышта җиңеп чыгачагына һичнинди шикләнүсез карый.* М.Хәсәнов

**ЧИГЕНЕШЛЕ** *с. лингв.* Алынма сүзләрдә, чыганак телдәгедән аермалы буларак, сүз ахырыннан сүз башына күчкән (басым тур.). *Чигенешле басым*

**ЧИГЕНҮ** *ф.* 1) Артка атлау, артка таба хәрәкәт итү. *Йөгереп барып, ишекне ача, йорт хуҗасын күргәч, уңайсызланып, артка чигенә.* А.Алиш

2) Берәр нәрсәдән ераккарак күчү. *Пыялачы күздән югалуга, малайлар дәррәү артка чигенделәр.* А.Гыйләҗев

3) Дошман һөҗүме нәтиҗәсендә тоткан позицияне калдырып артка китү. *Безне чигенергә мәҗбүр иткән дошманны шул ук юллардан кирегә куу-да катнашасым килә.* В.Нуруллин

4) *күч.* Элекке фикердән, карардан кире кайту, кире уйлау. – *Ну ярый алайса, – диде бу, һич тә чигенер чамам булмавын сизенеп.* В.Нуруллин. *Әмма Моторның хуҗасы безнең белән сөйләшергә дә теләми. Әтинең дә чигенер исәбе юк.* А.Хәсәнов

5) *күч.* Хәзерге вакыттан үткәнгә күчү. *Бер унбиш-егерме елга артка чигеник әле.* А.Тимергалин

**Чигенә бару** Торган саен чигенү. *Интәшем боларны күрүгә агарынды, теле бәйләнде, бер сүз дәшә алмый, ирексез артына таба чигенә бара, чигенә бара...* Г.Ибраһимов. *Күңелне сыкраткан авыр күләгә каядыр артка, мохитнең аргы ягына чигенә барды.* А.Вергазов

**Чигенә башлау** Чигенергә тотыну. *Ә безнең алгы сызыктагы пехотачылар, каушап калып, тәртипсез рәвештә чигенә башлаганнар иде.* В.Нуруллин. *Ислам кәләпүшне бисмилла әйтеп кия дә, тылсымлы сүзләр әйтеп, акрынлап артка, мәгарә түренә чигенә башлый.* А.Гадел

**Чигенә төшү** Бераз чигенү; тагын да чигенү. *Шул чагында Хәлил, үзенең чын хәленә кайтып, исерек булуын исенә төшерде һәм, шуны сиздерүдән гаять куркып, арты белән киоскыга таба аз гына чигенә төште.* Ә.Еники. *Эльвир, артка чигенә төшеп, караңгыда бик зур күренгән кулы белән үзенә таба кат-кат ишарә ясады ---.* М.Маликова

**Чигенеп бару** Акрынлап чигенү. *Мирвәли акрын гына чигенеп бара.* А.Гыйләҗев. *Тик сирәгәйгән бүре төркеме инде башкача һөҗүм итәргә кыймый чигенеп бара иде.* З.Мурсиев

**Чигенеп кую** Кинәт бераз чигенү. *Ибәтулла агай тагын артка чигенеп куйды.* М.Галиев. *Чәпәләй белән Тәпәләй, үзләре дә сизмәстән, артка таба чигенеп куялар.* Л.Лерон

**Чигенеп тору** Һәрдаим чигенү, гел чигенү; вакытлыча чигенү. – *Без вакытлы рәвештә чигенеп торабыз, – диде ул.* А.Алиш. – *Син гаскәреңне җый да юри генә чигенеп тор, кенәз, – дип, хыянәтче бояр шундук җавап сүзен әйтте.* В.Имамов

**ЧИГЕРҮ** *ф.* 1) Берәр нәрсәне, кемне артка этәрү, чигендерү. *Мин җәһәт кенә почмак якка узыйм дисәм, апай мине ишек төбенә кире чигерде.* Г.Бәширов. *Исмәгыйль, тагын да ачуы чыгып, машинаны артка чигерде дә, газга басып, капка баганасын ук сөздерде.* З.Мәхмүди

2) Берәр нәрсәне, эш башкару вакытын соңгарак күчерү. *Тәңре! чигерче яшемне, синнән сорыйм; Теләгемне синнән сормый, кемнән сорыйм ---.* Г.Тукай. *Баштарак мин вакытны берәр минутка чигерү белән чикләндем.* А.Тимергалин

3) Исәпләгәндә суммадан, берәр нәрсәнең микъдарыннан беркадәрен калу, киметү. *Йөкләр янына чыккач карасак, теге җитмәгән ашлыкны безнең өстән чигергән икән.* А.Гыйләҗев. *Бу суммадан фатир һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүне чигерсәң, калган акча ипи һәм сөткә дә җитмәячәк.* Ф.Зариф // Бирелергә тиешле суммадан беркадәресен тотып калу. *Күр әле, шофёр абыйның бушка концерт тыңлыйсы килгән икән! Билет бәясеннән чигерермен!* М.Хуҗин. *Ул-бу була калса, зарплатагыздан чигерәм, белеп торыгыз.* Л.Ибраһим-Вәлиди. *Сортларны кабат барлап чыгу – биш меңне чигерә.* Казан утлары // Гомумән нәрсәнедер киметү. *Кабул итсә, Ходай кичерер. Җүн гамәлем булса алда күбрәк, Гөнаһларны бераз чигерер.* Р.Зәкуан

4) Берәр сумманың беркадәрен нинди дә булса максат белән бүлеп бирү, өлеш чыгару. *Табыштан чигерүләр – бюджет доходларының әһәмиятле чыганакларыннан берсе.* Социалистик Татарстан

5) *махс.* Берәр нәрсәне тотылган яки яраксыз дип рәсмиләштереп исәптән чыгару

6) *күч.* Билгеле нияттән, фикердән кире кайтару. *Юк, Сөләйманны ниятеннән биздерү дә, кире чигерү дә мөмкин түгел, аның күзләре учак сыман дөрләп яна иде.* В.Имамов. *Ания, ирне яман ниятеннән чигерергә теләп, йөзенә, тавышына кырыслык салып: – Кагылып кына кара, барысын да хатыныңа сөйләп бирәм! – диде.* Р.Габделхакова

7) *күч.* Берәр эшне икенче планга кую, әһәмиятен киметү. *Әдәбиятның, шул җөмләдән драматургиянең дә, темалар-проблемалар байлыгына игъ-*

*тибар хәзер дә артка чигерелә алмый.* А.Әхмәдуллин

8) Үсешен, алга китешен тоткарлау, киметү, артта калуга сәбәпче булу. *Бу ачы, аянычлы язмыш минем үземне дә җирдән куптарып, җанымны кузгатты, күңел терәүләремне какшатты, офыкларымны артка чигерде.* Г.Гыйльманов

**Чигерә бару** Бер-бер артлы чигерү. *Шул чакта Ирек үзен үзе йөгәнләде, олы максатын һаман киләчәккә чигерә барды.* Ф.Садриев. *Сүзьясагыч кушымчалар ярдәмендә ясалган сүзләр нигез сүздән аста, баскычлап артка таба чигерә барып урнаштырылды ---.* И.Сабитова

**Чигерә башлау** Чигерергә тотыну. *Шуннан мәрхәмәтле хөкемдар әкренләп чигерә башлый.* Р.Кәрами

**Чигерә килү** Әлегәчә чигерү. *Табибка барырга курка, чигерә килә ул көнне.* Ш.Галиев. *Әти кеше, юк сәбәпне бар итеп, малай зарыгып көткән ул көнне чигерә килде.* Р.Мөхәммәдиев

**Чигерә тору** Һаман чигерү. *Ә без монда, михнәт чигеп, шайтан белсен, каядыр омтылабыз да омтылабыз, тормыш бәхетләрен һаман иртәгәсе көнгә чигерә торабыз...* З.Мифтахов

**Чигереп бару** Әлегәчә даими чигерү. *Шунысы да мәгълүм булсын: быел диспансеризацияне 1994, 1991, 1988 (һәм шулай өч елга чигереп барып) елда туганнар үтә.* Туган як. *Җитмәсә, минем янга килү, күчтәнәчләр алу өчен тоткан акчаларын исәпләп, шул акчадан чигереп бара икән.* Кәеф ничек?

**Чигереп җибәрү** Кинәт чигерү. *Мулланы да артка таба чигереп җибәрде, егерме метрлар читтә басып торган солдатларына, ике бармагын күтәреп, искәртү командасы бирде.* Ш.Маннур

**Чигереп килү** *к.* **чигерә килү**. *Аларны [нефть һәм газ ятмаларын] эшкәртү мәсьәләсен Америка һәрвакыт чигереп килде ---.* Р.Вәлиев

**Чигереп кую** Тиз генә чигерү. *Ләкин вакыйгалар, көтмәгәндә бер борылыш ясап, Георгий проблемасын беразга арткарак чигереп куйдылар.* И.Хуҗин

**Чигереп ташлау** Тиз арада чигерү. *Эшләр болайга киткәч, җитмәгән әйберләрне чигереп ташлау өчен, колхозчыларның гомуми җыелышын җыйдылар.* В.Нуруллин. *Әллә инде егет кеше белән булуы аңа ун елын чигереп ташларга ярдәм итте?* Ф.Яхин

**Чигереп тору** Вакытлыча, әлегә чигерү. *Ястү намазын уку вакытын төгәл генә әйтеп бирә алмасалар да, Пәйгамбәрнең аны төннең өчтән бере, хәтта яртысы үткәнче чигереп торуы хакында риваять ителә.* А.Тимергалин. – *Бар, ник булмасын, – диде теге пристав, – куып чыгару эшен егерме дүрт сәгатькә чигереп торып була ---.* К.Кәримов

**ЧИГЕШ** *и.* 1) *к.* **чигү** II. *Югарыда әйтелгән кызлардан күпләре тегеш, чигеш, нәкышь һөнәрләре үгрәндекләре кеби, өсләрендә улган киемнәре үз куллары илә тегелмеш вә эшләнмеш, имеш.* Р.Фәхретдин. *Бирнәгә дип чигү чигә-чигә, Кулларыннан гөлләр тамызган. Шома чигеш, хач чигүле чигеш, Шакмак чигеш... япма, пәрдәләр...* Ф.Дәүләтгәрәева

2) Чигелгән бизәк. *Төрле төстәге, төрле зурлыктагы чигешләр, каймалар кояшка каршы ялтырарга тотынды.* Г.Исхакый. *Бераздан үзе суккан, читләре матур чигешләр белән чуарланган ашъяулык, җәймә, кашагаларга да чират җитте.* Г.Әдһәмова

3) *куч.* Бизәктәй бормалы-сырмалы язу рәвеше. *Шулай итеп, кытай милләте үзенең мәңгелегенә бару юлында ике төрле дивар сагында кала: ил-җирен таш дивар белән каймалый, тел, рухи мирасына иероглиф чигеше белән калкан куя.* М.Галиев

**ЧИГЕШЛЕ** *с.* Чигүле, чигеп бизәкләнгән, бизәкләп чигелгән. *Хатынкызлар – бөрмәле, чигешле, көймәнле туннар, ә ирләр сары тун, постау тун киеп йөргәннәр.* Н.Максимов. *Ярый әле, апамнар аларның ак, чигешле пәрдәләрен корып куйдылар.* Ф.Яхин

**ЧИГҮ** I *ф.* 1) Төрле ысуллар кулланып, махсус энә һәм җеп белән тукымага бизәк төшерү. *Тамбурлап яки тоташ чигеп бизәлгән юка, аксыл, өчпочмаклы зур яулык.* Г.Ибраһимов. *Син кич утырып чигеп салган кулъяулыклар менә хәзер дә түш кесәмдә.* А.Хәсәнов

2) Гомумән чигештәге кебек бизәк төшерү. *Төрекмән келәмен кабер ташы өстенә мозаика белән чигеп ясау Рудиның үз васыяте иде.* Р.Мөхәммәдиев

**Чигә башлау** Чигәргә керешү. *--- кызлар киергеләрене киереп, балтыр чүпрәкләр челтәрли, якалар чигә башлагач, Сөннәтче бабайларда да хәл үзгәрә, аларның өйләре дә әллә нинди зур эшкә хәзерләнә башлый иде.* Г.Исхакый. *Кызлар тегү тегә, калфак чигә башлый – тормыш әкренләп көйләнә бара.* Т.Әйди

**Чигеп алу** Тиз арада яки бераз чигү. *Ялга бәйләр ак яулыкка Чигеп ал кояш кына!* Л.Зөлкарнәй. *Эшкә киткәнче, иртәнге сәгать дүрттә торам да бәйләп, чигеп алам, күңелемә шулай тынычлык табам.* Шәһри Казан

**Чигеп бару** Даими чигү; тоташтан чигү; нәрсәдер өстен эзлекле рәвештә чигү белән каплау. *Кулъяулыкның почмакларына ул шәмәхә дебет белән канәфер чәчәкләре чигеп бара.* Г.Бәширов. *Араларны якынайтып, Хатлар бергә тегеп бара. Тегеп бара, чигеп бара, Беленми дә кала җөе ---.* Х.Әюп

**Чигеп бетерү** Тулысынча чигү, бөтенесен дә чигү. *Таҗын гына чигеп бетерәм дә ял итәргә кирәк.* Р.Сәгъди. *Мавыгып китеп, өйдәге мендәрләрне дә чигеп бетердем.* З.Мәхмүди

**Чигеп кую** Алдан чигү. *Кагарлык капкам булмаган, сөйгән ярым уңмаган: яулык чигеп куймаган, сөлгесен тукымаган, тастымалын юмаган, иртәгә сабан.* К.Тинчурин. *Ә үзләре, егетемә дип, иң матур кулъяулыкны кышын кич утырганда ук чигеп куйган булалар.* Г.Гомәр

**Чигеп тору** Даими чигү; әле, хәзер чигү. *Бер мәртәбә ул, бүлмәдә чигеш чигеп тора торган Галимәне күрсәтер өчен: «Хәзрәткәем, бүлмәдән комганыңны үзең ал! Сыерым моңаеп тора», – дип, Галимә өстенә кертте.* Г.Исхакый

**Чигеп чыгу** Тулысынча чигү, башыннан ахырынача чигү. *--- Үзәк Азия төрки-монгол халыкларына күлмәк һәм аякчу кырыйларын вензельләп каймалап чигеп чыгу хас ---.* Р.Әхмәтьянов. *Күләмле картинаны төсле җепләр белән чигеп чыгарга ай-һай нинди сабырлык кирәк бит!* Кайбыч таңнары

**Чигеп утыру** *сөйл. к.* **чигеп тору**. *Хәзер кем кулъяулык чигеп утырсын...* Р.Зәйдулла

**Чигеп яту** *сөйл. к.* **чигеп тору**. *Галиябану, чигеп яткан эше кулында көенчә, өстәл янында тыңлап утыра.* И.Юзеев

**ЧИГҮ** II *и.* 1) Җеп яки башка нәрсә белән бизәк төшерү эше. *Чигү чигеп утырмаса.* А.Әхмәтгалиева. *Өйдә чигү чигеп тик утырды.* Г.Гыйльманов

2) Шундый ысул белән бизәкләр төшерелгән эш. *Хан кызының туган көн тантанасында кем мактанган иде, чигүләрен күрсәтә-күрсәтә?* Н.Сәйяр

**ЧИГҮ** III *ф. к.* **чигенү**. *Мансур, күзләрен мөлтәйтеп, аңа бераз карап торды да, артка чигеп, караватка утырды, тагын юеш башын сөртә башлады.* Г.Әпсәләмов. *Ләкин алай итмәде Микәй, артка чигеп, дәү тәкәнең яңадан уртага чыгуын көтте.* Р.Мөхәммәдиев

**Чигә бару** Акрын гына һаман чигү. *Әйе, күңелле вакытлар, яшьлек дуамаллыклары, эчмичә исерек чаклар акрынлап артка чигә бара икән... һәм кешенең күңеле дә басыла төшә икән.* Р.Кәрами. *Солтанъяр бүредән күзен алмый, акрын гына чигә бара, чигә бара...* З.Мурсиев

**Чигә башлау** Чигәргә тотыну. *Валя, күзләрен акайтып, артка чигә башлады.* З.Мәхмүди. *Көтелмәгән хәлдән Сәет артка ук чигә башлады...* Г.Гыйльманов

**Чигә төшү** Бераз чигү. *Баягы куанычлар чигә төште.* Ф.Сафин

**Чигеп кую** Кисәк чигү. *Дәү тәкәнең авырлыгыннан аяклары, ирексездән, артка чигеп куйды, ул үзенең шул кызыл ярдан тәгәрәп төшеп китүен сизми дә калды.* Р.Мөхәммәдиев. *Тезләнгән килеш арткарак чигеп куйдым...* Г.Гыйльманов

**Чигеп тору** Әлегә чигү. *Ханымнар шулай бераз уфтанышып алдылар да тындылар, ни әйтсәң дә, бәйрәм көн шул, дөнья мәшәкатьләре арткарак чигеп тора торган көн.* Татарстан яшьләре. *Авыртулар артка чигеп тора ---.* Биектау хәбәрләре

**ЧИГҮ** IV *ф.* 1) Тарту, төтенен үпкәгә суыру. *Мәдрәсәдә хәлфәләр кайсы тәмәке чигә, кайсы вак сала.* З.Һади

2) Ниндидер хәлгә дучар булып шуңа түзү, ниндидер хис кичерү. *Бер нужа чигеп, Лаеш шулпасын эчеп кайтса, китәм дигән тыны булмас иде.* А.Гыйләҗев. *Мин дә гел михнәт чигеп кенә яшәү ягында түгел.* В.Нуруллин

3) Нәрсәнедер йөреп, күреп, үтеп чыгу, шуннан тәм табу. *Мондый гадәти булмаган төннән соң, бар дөньяны онытып, сәхрә чигеп йөрүгә ни җитә!* Т.Әйди. *Йөреп чыгыйк әле, бер күрешкәч, чигеп чыгыйк әле Казанны.* Р.Мингалим. *Мин – сине сөйгән егет, Эзлим сиңа илткән юлны, Җитмеш җәһәннәм чигеп.* Р.Гаташ

**ЧИГҮЛЕ** *с.* Чигелгән, чигү белән бизәкләнгән. *Шунда инде мин тәүге тапкыр башыма милли калфак, өстемә чын милли күлмәк, аягыма чып-чын чигүле читекләр кидем.* Л.Шагыйрьҗан. *Билләргә салынган чигүле сөлгеләр менә-менә өзелеп китәр кебек иде.* З.Мәхмүди

**ЧИГҮЛЕК** *и.* Чигә һәм чигелә торган әйберләр. *Чигүлекне җыеп кую*

**ЧИГҮЧЕ** *и.* Чигү белән мәшгуль кеше, чигә торган кеше, чигү остасы. *Каян килгән чигүче?* Г.Сабитов. *Заманында әби дә, әни дә оста чигүче булган.* А.Сабирова

**ЧИЕРТЕШ** *и. к.* **чиртеш**. *Икенче бер төркем карта уйнарга керештеләр. Борынга чиертештән җибәрә иделәр...* Ш.Камал

**ЧИЕРТКЕ** *и. к.* **чиртеш**. *Хәзер Зәкинең эше җайланды: атнага бер-ике дәрес ала да, үзенең зирәклеге сәбәпле бик тиз белеп, башка заманда буш – укымый үткәрә; өйләгәчә аш пешерә, өйләдән соң ашап йоклый, кич берлә чиертке, карта, шатранҗ кеби уеннарның берсе илә шөгыльләнә иде.* Г.Ибраһимов

**ЧИЕРТКЕЧ** I *и. к.* **чирткеч** I

**ЧИЕРТКЕЧ** II *и. диал. к.* **чирткеч** II

**ЧИЕРТЛЕК** *и. диал.* Кузна. *15–20 пар шундый чиертлекләрне учың белән җиңелчә генә өстәлгә яки идәнгә, яки сәкегә сибеп җибәрәсең.* М.Харисов

**ЧИЕРТТЕРҮ** I *ф. к.* **чирттерү** I. *Маңгаегызга чиерттерсәгез, билет алып бирәм үзегезгә.* Ф.Яруллин. *Без балачакта ул түр тәрәзә янындагы сәкегә сузылып ятар иде дә, мандолинасын түшенә куеп, моң гына чиерттерер иде.* Ә.Маликов

**ЧИЕРТТЕРҮ** II *ф. к.* **чирттерү** II. *Шулай да берара халык телендә, Мостафинның Нәҗиясе раймагтагы кара мыеклы егет белән чиерттерә икән, дигән хәбәр йөргән иде.* Ә.Еники. *Аннан син аның хатынын чиерттерәсең бугай, ә?* Г.Каюмов. *Кассадан акча чиерттерү*

**ЧИЕРТҮ** I *ф. к.* **чиртү** I. *Кайбер вакыт эчең поша, вакытны ничек үткәрергә гаҗизсең, эшсезлектән бизәсең, каравылның аяклары ераклашканын көтеп торасың да янәшә камерадагы тоткын белән таш диварга чиертеп сөйләшә башлыйсың.* Г.Ибраһимов. *Әйтик, мин синең маңгаеңа ун тапкыр чиертәм, һәм син миңа... моның өчен рәхмәт әйтәчәксең!* А.Гыймадиев. *Уртага сирәк кенә озын сакаллы бер карт кулына сигез кыллы думбра алып чыгып җырларга һәм думбраны чиертергә тотынды...* Г.Гобәйдуллин

**ЧИЕРТҮ** II *ф. к.* **чиртү** II. *Молодец, чиерттең бит асыл кошны.* М.Фәйзи. *Дүрт-биш тәңкә чиертә, дип торганда гына харап булдым!* Г.Камал. *Гаҗәпләнеп торма, тартып ал кармагыңны, әнә бит ничек көчле чиертә.* А.Гадел. *Тукта, минәйтәм, куып тотып, берәр тәмәкесен чиертим әле, бер уңайдан кем икәнен дә белермен, дидем.* И.Хәйруллин

**ЧИЕРТҮ** III *ф. к.* **чиртү** III. *Шуңа күрә Зифа иртә-кичен берәр җамаяк көнбагыш өеме чиертеп утырырга мәҗбүр.* В.Имамов

**ЧИЕ́Р-ЧИЕР** *иярт.* Кайбер кошларның сузыбрак сайрау, черелдәү тавышын белдерә

**ЧИЕ́Р-ЧИЕР ИТҮ** *ф.* Чиер-чиер килгән тавыш чыгару

**ЧИЕ́Р-ЧИЕР КИЛҮ** *ф. к.* **чиер-чиер итү**

**ЧИ́ЗБУРГЕР** *и. ингл.* Сыр белән ясалган гамбургер. *Һәркемнең диярлек, чизбургер һәм, сырлы соуска манамана, фри бәрәңгесен дә татып карагагы бар.* Идел. *Бездә киресенчә, кызларга хөрмәт күрсәтәләр, аларга туңдырма, чизбургер алып бирәләр...* Көмеш кыңгырау

**ЧИ́ ИТҮ** *ф.* Чыелдау. *Тычкан нечкә тавыш белән чи итеп куйды һәм --- тәгәрмәч уйган канау буйлап йөгерде.* Г.Гобәй

**ЧИК** *и.* 1) Нәрсәне дә булса аеру өчен махсус билгеләнгән сызык; ызан. *Син үзең сажинны ал да, үлчәп, чикләрен таптап кайт.* Г.Ибраһимов // Күрше дәүләтләрнең җирен, мәйданын берберсеннән аерып торган сызык. *Беләсезме, Антарктика картасында да чикләр үткәрелми.* А.Тимергалин. *Тайгада, бигрәк тә чик буенда, кем йөрмәс?* А.Хәсәнов // Административ бүленешне күрсәтеп торган шартлы сызык. *Карательләрнең якынлашуы турындагы хәбәрне алуга, Әбҗәлил, волость чикләрен саклау өчен, ашыгыч чаралар күрә.* В.Имамов

2) Берәр нәрсәнең кырые, чит сызыгы. *Шуңа да икенче бүлектә хронологик чикләр киңрәк чорны, әйткәнемчә, ике дистә елны иңләп ала.* А.Әхмәдуллин. *Җир тирәли стратосфера чикләрендә әйләнеп йөргән беренче пилотларны стратонавт дип атау да мөмкин түгелдер инде.* А.Тимергалин. *Дөньяның чикләре киңәйгән бу сурәтләрдә.* Г.Гыйльманов

3) Гомуми кабул ителгән, рөхсәт ителгән норма, кыса. *Күбәләкнең бер дә чик юк һәр матурга гыйшкына: Тиз генә ул барды да кунды матур зат өстенә.* Г.Тукай. --- *Буйсынулар таләп ителгәндәй, Ул һаман бер чик белән бара.* А.Нәҗми

4) *күч.* Чикләп торган нәрсә, киртә. *Килер бер көн, алар күкрәктән ташып, ургылып чыгар, шагыйрьнең мөкатдәс васыяте булып, буыннарга калыр, аларга чикләр дә, киртәләр дә, төрмәләр дә булмас, туган илгә барып җитәр.* Г.Әпсәләмов

5) *күч.* Нәрсәнең дә булса ахыры. *Бу чик артында – үлем.* Г.Әпсәләмов.

*Ә табигатьне өйрәнүдә бер-бер чик бармы соң?* А.Тимергалин // Берәр эш яки хәлнең соңгы дәрәҗәсе. *Таҗны даулап кызып китте, ди, тәмам үләр чиккә җитте, ди [Капкорсак патша].* А.Алиш. *Йөрәк шартлар чиккә җитә.* А.Гадел

6) *күч.* Берәр әйбернең асыл билгесенең критик ноктасы, мөмкинлекнең соңы. *Эластиклык чиге сузылудан калган деформация 0,05% тан артмаган көчәнеш белән бәяләнә.* Төзү материаллары

◊ **Чик кую** Тыю; туктату, бетерү, чикләү. *Разия генә ул сүзләргә чик куярга теләде ---.* А.Алиш. *Бу башбаштаклыкка һич кичекмичә чик куюын сораячакмын.* А.Хәсәнов. *Әмма ләкин аңа сәбәп булган нәрсәләрнең еш кабатлануы, мөнәсәбәтләргә чик куеп, араны өзүгә китереп җиткерүе ихтимал.* Г.Бәйрәмова. **Чиктән ашу** Мөмкин булган кысалардан чыгу, норманы бозу. *Бусы инде чиктән ашты.* А.Гыйләҗев. *Сагынуларым чиктән аша ---.* А.Әхмәтгалиева. **Чиктән ашкан** Искиткеч, югары дәрәҗәдәге. *Чиктән ашкан нахаллар димичә, ни дисең инде?!* Г.Гомәр. **Чиктән тыш** Чамадан тыш, бик нык. *Андагы чиктән тыш каты тәртипләрдән, һәр адымны күзәтеп торучы рәхимсез тәрбиячеләрдән туеп, --- ул Агыйделне, аның тугайларын, иреген сагынган.* Г.Әпсәләмов. *– Ә син каян белдең «Альф»ның мин икәнен? – дип сорады ул, чиктән тыш гаҗәпләнеп.* А.Гыймадиев. **Чиктән узган** *к.* **чиктән чыккан**. *Онның поты чиктән узган чакта, Кем түйдырган, кием кигезгән?* С.Хәким. **Чиктән узу** *к.* **чиктән ашу**. *Әмма кайнанам мине хыянәтче дип атагач, эш чиктән узган иде инде.* Ватаным Татарстан. **Чиктән чыгу** *к.* **чиктән ашу**. *Беләсеңме, кайчагында хыял чиктән чыга, күңелдә кайный башлый...* Н.Кәримова. *Шулай кызыгып йөри торгач, түземем чиктән чыгып, матайга утырып карарга булдым.* Р.Вәлиев. **Чиктән чыккан** 1) Искиткеч, бик югары дәрәҗәдәге. *--- әмма чиктән чыккан бәяләр булмаячак ---.* Безнең гәҗит; 2) Чикне оныткан. *Бу хәл ни белән бетәр иде, көтмәгәндә кайсыдыр бер оста үзенең ни кылуын аңлар чиктән чыккан хуҗаны җилкәсеннән эләктереп алды.* Кәеф ничек?

**ЧИКЕРТКӘ** *и. зоол.* 1) Чын чикерткәләр семьялыгыннан озынча тар гәүдәле, ата затларының өске канатлары астында черелдәвек тавыш чыгара торган органы булган бөҗәк; *русчасы:* **кузнечик**. *Каралтма кальбеңи, ашап кикермә, – Игендәге чикерткәдәй сикермә.* Г.Тукай. *Тау сыртындагы корыган үлән чылгыйлары, корышкан абагалар арасында тынгы белмәс чикерткәләр скрипкәләрен уйныйлар.* А.Гыйләҗев

2) Чын чикерткәләр семьялыгыннан көздән язга кадәрге вакытны өйләрдә, җылытылган биналарда үткәрүче саргылтрак тар гәүдәле бөҗәк; өй чикерткәсе; *русчасы:* **сверчок**. *Мич артында чикерткәләр сайравы белән геренә кайчы асылган сәгатьнең келт-келт йөрүе генә ишетелә.* С.Зыялы. *Мин, мич артында чикерткә чырылдаганын тыңлап, сәке өстендә озак кына боргаланып яттым.* Т.Нурмөхәммәтов

3) *күч.* Ябык кына тиктормас кыз. *Әллә бензин эчтеңме? Әллә шул чикерткә аркасындамы?* Г.Каюмов. *Көн саен кием алыштыра торган гадәте белән бу чикерткә беренче айларда ук бөтен коллективны шаккатырды.* В.Имамов

4) *күч.* Эштән эшкә күчеп йөри торган кеше

5) *күч.* Кечкенә очкыч. *Зәйнең үзенә ун урынлы чикерткәләр генә йөри.* А.Гыйләҗев

◊ **Чикерткә куып йөрү** Эшсез йөрү, вакытны бушка уздыру

**ЧИКЕРТКӘ́ ЧЫПЧЫК** *и. зоол.* Чикерткә чыпчыкчалар семьялыгыннан чикерткә тавышына, үлән кыштырдавына охшаш тавышлар чыгарып сайрый торган кечерәк кош; *русчасы:* **сверчок**

**ЧИКИ** *и. рус сөйл.* Кечкенә шешә. *Замның каймак ашаган песи кебек канәгать йөзле бичәсе, тун кесәсендәге чикиен – бәләкәй шешәдәге аракысын капшап, үзенә әчәргә дус эзләргә кереште.* Г.Мирһади

**ЧИ́К-КЫРЫЙ** *и. к.* **чик-чама**. *Эшнең чиге-кырые юк*

**ЧИКЛӘВЕК** *и.* 1) Чикләвекчәләр семьялыгыннан киң яфраклы һәм катнаш урманнарда үсә торган, каты кабык эчендә ашарга яраклы төше булган куак. *Безнең урман – җиләк һәм чикләвек оясы, дип әйткән идем инде мин сиңа.* В.Нуруллин

2) Кайбер куак һәм агачларның каты кабык эчендәге ашарга яраклы төше. *Шәһәр башлыгы әмере буенча, бу каланың урамнарына әчтерхан чикләвеге токымыннан кыргый чикләвек агачлары утыртылган булган икән.* Г.Кутуй. *Тайга анда, --- кедрлар үсә, кедр чикләвеге җыеп алып кайтырсың күчтәнәчкә, аяк асты тулы мүк җиләге – җәннәт, бер сүз белән әйткәндә.* К.Кара

**ЧИКЛӘВЕКЛЕК** *и.* Чикләвек куаклары (агачлары) үсә торган урын. *Инде көнчыгыштан, чикләвеклек белән капланган калкулыклар артыннан, сызылып кына, алсу таң атып килә.* Ә.Сәлах

**ЧИКЛӘВЕК ЧЫПЧЫГЫ** *и. зоол.* Карга кошлар семьялыгыннан нигездә эрбет чикләвеге белән туклана торган куе коңгырт төстәге кош; эрбет чыпчыгы; *русчасы:* **кедровка**. *Алар аркаларын терәп диярлек утырган урман эченнән чикләвек чыпчыгы сызгыргалаганы --- ишетелә иде.* Сөембикә

**ЧИКЛӘГЕЧ** *и. тех.* **1.** 1) Берәр нәрсәне чикләү чарасы буларак ясалган нәрсә. *Юлларны төзекләндерү, ремонт ясау, юл кырыйларына өстәмә чикләгечләр кую һәм юл хәрәкәте иминлегенә тискәре йогынты ясаган башка проблемаларны да тиз арада хәл итәргә кирәк.* Яңа тормыш

2) Машинаның, аппаратның эшләү мөмкинлеген чикләп куя торган җайланма, әсбап. *Азык салу ачык улаклары чикләгечләре терлекнең яшенә карап көйләнәчәк.* Йолдыз

3) Транспорт чараларының тизлеген киметү өчен, юлда махсус ясалган калкулык. *Кызылармиячеләр урамында да машинаның тизлеген ирексездән киметергә мәҗбүр итә торган ясалма чикләгеч моннан өч ел элек булдырылды.* Йолдыз

**2.** *с. мәгъ.* Нәрсәне дә булса чикли торган. *Ике катлап теккәндә, чикләгеч линейкадан файдаланырга мөмкин, ул чагында җөй тагын да тигезрәк була.* Файдалы киңәшләр. *Монда чикләгеч һәм кисәткеч билгеләр торса да, светофор бик урынлы.* Авыл таңнары

**ЧИКЛӘМӘ** *и.* 1) Берәр нәрсәдән чикләү чарасы. *--- өч рәт белән кәрниз чыгарып өстен ябу, янгынга каршы чикләмә ясап түшәмне чыгу өчен генә дә ике сәгатьләп вакыт үтә.* Безнең гәҗит

2) *мат.* Чикләнмәгән дәрәҗәгә якыная торган даими зурлык. *Әйләнәнең озынлыгы, аңа камаулы яки аны камаучы күппочмакның яклары санын чикләмәгән рәвештә арттырганда, күппочмакның үзгәрешле периметрына омтылган чикләмә дип карала.* Югары математика нигезләре

**ЧИКЛӘНГӘН** *с.* 1) Чикле; саны, күләме, микъдары билгеле чикләргә кадәр булган. *Һавага зарарлы матдәләрнең чикләнгән микъдарда чыгуы әлеге*

*кешеләрне буылдырып, аяктан екмый дигән сүзме?* А.Вергазов. *Совет гаскәрләренең чикләнгән контингенты составында Әфганстандагы сугыш операцияләрендә катнаша.* Г.Мөхәммәтшин

2) *мат.* Билгеле бер шартларда чиге булган, билгеле бер зурлыктан артмаган. *Чикләнгән зурлык*

3) *махс.* Кулланылышы чикле булган, ачылмый торган. *Чикләнгән файл*

4) *күч.* Тар; кимчелекле. *Чикләнгән тормышта булган файда һәм ләззәтләрнең акыл каршында кыйммәте юк.* Г.Баруди. *Шикләнгән кеше – чикләнгән кеше, ул алга бара алмый.* З.Мурсиев

5) *күч.* Аз белемле, тар карашлы, чикле. *Мин чикләнгәнрәк кешедер, бәлки.* Т.Әйди

**ЧИКЛӘНГӘНЛЕК** *и.* Чиклелек, чикләнгән булу күренеше. *Хәер, анда да чор идеологиясенә хас чикләнгәнлекләр үзен нык сиздерә иде...* М.Госманов. *Бу фәлсәфәдә кемдер чикләнгәнлек, хилафлык күрер, әмма бу фәлсәфә – дөньядагы иң кешелекле һәм шәфкатьле тәгълиматларның берсе!* Г.Гыйльманов

**ЧИКЛӘНМӘГӘН** *с.* 1) Чиге булмаган, чик куелмаган, чиксез. *Ләкин алар миндә чикләнмәгән көч барлыгын исәпкә алмыйлар.* Т.Гыйззәт. *Аның көчлелеге, чикләнмәгән киңлеге, ак күбекләр чәчеп үкергән дулкыннары, ачы тавышлар белән кычкырып очкан акчарлаклары!..* Г.Әпсәләмов. --- *Шәһи-Котык улына император чикләнмәгән власть бирә.* А.Хәсәнов

2) *мат.* Чиге билгеле булмаган. *Чикләнмәгән функция*

**ЧИКЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **чикләү**. *Акча лимиты чикләнгән*

2) Берәр эштә инде булганыннан канәгать калып тукталу; зурга җибәрмәү. *Әмма әйттеләр: председатель булып әле күптән түгел генә эшли башлавыңны искә алып, шелтә бирү белән чикләнәбез, әгәр тагын шундый берәр мөгез чыгара калсаң, үзеңә үпкәләрсең, диделәр.* В.Нуруллин. *Камал апа белән икебезгә дә эләгә. Сугу, кисәтү белән чикләнәләр.* Г.Гомәр

3) Билгеле бер кагыйдәләрдән тайпылмау, кысадан чыкмау, шулар эчендә эш итү. *Ә тактик дәресләр исә экипажларның танк маршрутлары буйлап җәяү йөгерүе белән генә чикләнә.* И.Хуҗин. --- *бу проблемага кыскача экскурс белән чикләник.* Б.Хәмидуллин

**Чикләнә бару** Торган саен чикләнү. *XVIII–XIX йөзләрдә Госманлы империясе бай Көнбатыш Аурупа илләренә бурычка бата, аның бәйсез тышкы сәясәт үткәрүе елдан-ел чикләнә бара.* Т.Әйди. *Галиҗәнап Китапның мәдәниятебезгә хезмәт итү мөмкинлекләре шактый тарая һәм чикләнә бара.* С.Шәмси

**Чикләнә башлау** Чикләнергә тотыну. *Борынгы греклардан һәм римлылардан килгән риторика жанры үзенең элекке нәфасәти сыйфатларын югалта, фәкать дини вәгазьләр белән чикләнә башлый.* К.Гыйззәтов. *Тәк, җиңелчә генә иреннәрне ясап кую белән генә чикләнә башладым.* Р.Гаязетдин

**Чикләнә төшү** Бераз чикләнү. *Нәтиҗәдә сәнгать әсәреннән ала торган яңалык тәэсире югала, тамашачының хыялы һәм фантазиясе чикләнә төшә.* Казан утлары

**Чикләнеп бару** Акрынлап чикләнү. *Бәлки, аның гомере чикләнеп барадыр, бәлки, аның санаулы көннәр генә яшисе калгандыр.* Н.Гыйматдинова

**Чикләнеп бетү** Бик нык чикләнү. --- *дөньяның әхлагы да иске «Фәзаилешшөһүр»ләргә генә кереп бетмәгән кебек, матурлык, нәфасәт хакындагы уйлар да иске әбиләрнең мәкальләре берлән генә чикләнеп бетмәгәндер.* Г.Исхакый

**Чикләнеп калу** Ахырда чикләнү. *Бүген никтер сөйләргә дә ашкынып тормый, хәтта Равил сүз кушканда да, кыска гына җавап бирү белән чикләнеп кала.* В.Нуруллин

**Чикләнеп килү** Әлегә кадәр чикләнгән булу. *Ләкин, гомумән алганда, революциягә кадәр Россиядә көнчыгыш илләр тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү күп очракта филология өлкәсе белән чикләнеп килде.* Ризаэтдин Фәхретдин: мирасы һәм хәзерге заман

**Чикләнеп тору** Әлегә чикләнү. *Сыйрат күпере хәлләреннән хәбәрләр шактый булу сәбәпле, аларның барчасын да сөйләп бетерү мөмкин дә түгелдер, хәзергә шушылар белән чикләнеп тордык.* Ф.Яхин

**ЧИКЛӘ́Ү** I *ф.* 1) Чиген, кырыен билгеләү. *Аларның төп тору урыннары Тау ягының төньяк өлеше була, аны төньяктан Идел, көнчыгыштан Зөя һәм көнбатыштан Сура елгалары чикли.* Б.Хәмидуллин. *Марилар үзләре урнашкан җир мәйданын чикләп, канау ясап, кәзләрне күтәреп чыккан булганнар.* Р.Зарипов

2) Чик кую; үсешенә тоткарлык тудыру; эшчәнлекне туктату. *Әгәр телнең кулланылыш даирәсен үз теләгебез белән чиклибез икән, ул, әлбәттә, инкыйразга юл тота.* А.Тимергалин

3) Билгеле чик эчендә тоту, кысадан чыгармау. *Уналты яшьтә кыз күңеленә чын мәхәббәт иңә икән, аны тыя, чикли, буйсындыра торган кодрәт юк.* А.Гыйләҗев. *Кешеләргә Алла акыл биргән, Акыл белән чиклик теләкне.* В.Галиев. ---- *заказ бирүче нинди биналарны ничегрәк салырга теләвен бәйнә-бәйнә әйтеп куйган. Өстәвенә аны «Төзү нормалары һәм кагыйдәләре» дигән нәрсә чикли.* М.Маликова // Нәрсәнең дә булса чик ноктасын билгеләү. *Әле күпләр безнең тарихны Болгар белән генә чиклиләр.* Х.Миңнегулов

4) Бетерү, тәмам итү. *Менә хәзер дә мин сүземне чикләп, рәхмәтемне әйтеп, кузгалырга булдым.* Ә.Еники

5) *күч.* Юкка чыгару, юк итү. *Өметсезлектә яткан кызга җан кереп китә, ул, дәртләнеп, эшкә тотына, ләкин... алты йөз кырык өч торна ясагач, мәрхәмәтсез үлем кызның гомерен чикли.* А.Гыйләҗев. *Гомер юлым синдә чиклим диеп теләсәм дә, Үлем алмады...* Р.Вәлиева

**Чикләп киту** Сүз уңаеннан чикләү. *К.Нәҗминең кирәкле тел чараларын сайлау принцибын җанлы сөйләм теле белән генә чикләп китү дөрес булмас иде.* Татар әдәби теле тарихы

**Чикләп килү** Әлегә кадәр чикләү. *Халык сәнгате промыселының үзенчәлеген искә алмау, әнә шулай итеп, безне һаман чикләп килә.* Ф.Латыйфи

**Чикләп кую** Кинәт чикләү. *Аллаһы Тәгалә, адәми затның фикерләүдә-хыяллануда чиксезлеккә ирешә алмаячагын белеп, аның фани дөньядагы тормышын чикләп куймадымы икән?..* М.Хуҗин. *Ә хәзер йөгереп йөреп тә, сөйләнеп тә булмый, машина кабинасы төрле яктан чикләп куйган.* М.Маликова

**Чикләп тору** Әле чикләү; даими чикләү; вакытлыча чикләү. *Мондый чакта бүлмә уйларны чикләп тора, күңел иркенгә тартыла иде.* Г.Бәширов. *Икенче берләрен чыганаклар, фактик материал булмау чикләп торган.* Р.Юныс

**Чикли бару** Торган саен чикләү; булган берсен рәттән чикләү. --- *ул, гади сөйләмне кысрыклап, аның кулланылыш мөмкинлекләрен чикли бара.* Ф.Сафиуллина

**Чикли башлау** Чикләргә тотыну. *Физик эшнең ләззәте, канәгатьлек бирүе һаман үзенә тарта, үзеннән җибәрми, берзаман чикли үк башлый ---.* Ш.Гали-

ев. *Ләкин әдәбият берьяклырак китсә, үзенең максатларын чикли башласа, теманың да чикләнүе мөмкин.* Р.Низами

**Чикли килү** Әлегәчә чикләү. *Тарихтан күренгәнчә, һәр халык хатынкызның алкоголь куллануын чикли килгән.* Безнең гәҗит

**Чикли төшү** Бераз чикләү; тагын да чикләү. *Чамадан тыш киң планлылык тулы канлы, калку индивидуаль образ гәүдәләндерү мөмкинлеген беркадәр чикли төшкән.* Ф.Хатипов

**ЧИКЛӘ́Ү** II *и.* 1) Кемнең дә булса хокукын кыскан, эшләренә тоткарлык ясаган нәрсә. *Министрлык төзегән чикләүләр таблицасы буенча нәтиҗә ясасаң, фенол зур зыянлы, куркыныч агу түгел.* В.Имамов

2) *махс.* Объектның аннан куллану, сыйфатын, хәлен һ.б.ш. якларын үзгәртү мөмкинлеге юк ителүдән гыйбарәт булган статусы; *русчасы:* **обременение**. *Залог – чикләүнең бер төре*

**ЧИКЛЕ** *с.* **1.** 1) Чиге булган, чиге күренеп торган. *Анда-санда куаклыклар, агачлыклар белән бүлгәләнгән – күз күреме чикле урыннар бар.* М.Маликова

2) Күләме, микъдары һ.б.ш. чикләнгән, билгеле бер чиге булган, чиге билгеле булган // Аз; тар. *Ләкин ул орлыкларның саны бик чикле, һәм алар авыру булу аркасында үрчи дә алмыйлар.* А.Расих. *Тик синең тормышың бик чикле, үз җаныңа очар урын юк!* А.Гыйләҗев. *Абзыйсы әллә нәрсә уйлар, аннан язмасы да пычрана, болай да бик чикле кәгазь дә әрәмгә китә.* А.Хәлим

3) *күч.* Тар карашлы, рухи яктан үсмәгән. *Димәк, моннан соң да алар шундый бик чикле, бик тар, йомык кеше булып калачаклар.* Г.Әпсәләмов. *Хәер, хатынкыз азатлыгы мәсьәләсендә дә Ф.Кәриминең карашлары чикле иде.* М.Мәһдиев. *Аларның баш миләре чикле!* Ф.Баттал

4) Берәр төрле шарты, чикләүләре булган. *Территориаль яктан кулланылышы чикле булган сүзләр диалектизмнар дип атала.* Ф.Сафиуллина. *Аның да, аңа кадәрге ханнарның да идарә итүдә хокуклары бик чикле була.* С.Әхмәтҗанова

5) *мат.* Билгеле бер чикләрдә үзгәрә торган, нульгә дә, чиксезлеккә дә тигез булмаган. *Чикле зурлык*

6) *лингв.* Төгәлләнүгә, бетүгә омтылган эш-хәрәкәтне белдергән. *Чикле фигыльләрдә эш үзенең логик чигенә омтыла, һәм эш чиккә җитү белән туктала, һәм башкаручы яңа халәткә күчә.* Ф.Хисамова

**2.** *бәйл. функ. диал.* Тикле, кадәр, хәтле. *Һи, моңар чикле ни карап тордым икән, шул корым карасы берлән гомер уздырдым ---.* Г.Камал. *Син ни чикле белсәң дә, акчаң булмаса, син кеше түгел.* Г.Исхакый

**ЧИКЛЕЛЕК** *и.* 1) Чикле булу күренеше; чиге, соңы билгеләнгән булу хәле. *Бу аска таба очуның ямьлелеге, тантаналы сагышы нәкъ шул чиклелегендә һәм тәмамланачагында лабаса.* З.Хәким. *Сайлау кампаниясе барышында кайчак вакыт тарлыгы һәм бюджет чиклелеге моны эшләргә мөмкинлек бирми ---.* Кызыл таң

2) Карашларның, фикерләү дәрәҗәсенең, белемнең һ.б.ш.ның тарлыгы. *Күрәсең, драма әсәрләренә хас чиклелек аларны да сагайта.* Казан утлары

**ЧИКМӘН** *и. тар.* Калын сукнодан тегелгән, элек авылда киелгән җылы өс киеме. *Ишек алдында озын чуар чикмән кигән, кулларына озын сөңге, биленә кылыч таккан, сул кулына ялтырап торган, төрле шигарьләр язган калкан тоткан кеше тора иде.* Г.Гобәйдуллин. *--- үзләре суккан киндердән күлмәк, үзләре баскан туладан чикмән кигәннәр.* Г.Рәхим

**ЧИКМӘНЛЕ** *с.* 1) Чикмән кигән. *Имеш, сары чикмәнле мужик егетләре белән китеп, анда бәрәңге ашап, ике тиенлек чуваш ефрейторларының итеген тазартып йөргән бер бичараны, аңа кияүгә барам дип, ничә ел көт!* Г.Ибраһимов. *Толыплы, чикмәнле авыл агайлары чаналарын бер-беренә терәбрәк, тартып-этеп куйдылар.* Р.Кәрами

2) Кабыгы белән пешерелгән (бәрәңге тур.). *Карап торам: боларның чикмәнле бәрәңгене күргәннәре, ашаганнары юк.* Н.Әхмәдиев. *Минә чикмәнле бәрәңге белән сало гына бар.* Л.Лерон

◊ **Чикмәнле бавырсак** *шаярт.* Кабыгы белән пешерелгән бәрәңге. *Өстәлгә, буларын бөркеп, олы тәлинкә тулы чикмәнле бавырсак һәм ак күбекләре ташып торган нәзек озын сыра бокаллары килеп утырды.* Ш.Маннур. *Чикмәнле бавырсактан соң күп итеп кәҗә сөте салып, авызны пешерә-пешерә, куе такта чәй эчәбез.* А.Хәсәнов

**ЧИКМӘНЛЕК** *с.* **1.** Чикмән тегәргә яраклы, чикмән тегү өчен билгеләнгән. *Янә памушник Мөхәммәдрәхим Йосыф угылына алты айга илле сум акча, янә бер чикмәнлек кызыл постау.* Гасырлар авазы

**2.** *и. мәгъ.* Чикмән тегәргә дигән материал. *Сиңа дигән чикмәнлекнең аршынын унике тәңкәдән алганнар, ди.* Г.Камал. *Әүхәдигә биш айга ун сум илле тиен көмеш саф акчалата һәм шул фабрикада эшләнгән бобриктан бер чикмәнлек кисеп бирделәр.* К.Тинчурин

**ЧИКСЕЗ** *с.* **1.** 1) Чиге билгеләнмәгән; кырые күренмәгән, очсыз-кырыйсыз. *Кошларга кирәк чиксез күк, Җырга кирәк иркенлек!..* Г.Гыйльманов

2) Беркайчан да бетми торган, мәңгелек. *Вакыт чиксез дә, чикле дә.* Г.Әпсәләмов

3) Гадәттән тыш, искиткеч. *Чишмә турында Әбүзәр абзый чиксез ярату белән, Тукай үзенең Кырлае турында сөйләгән кебек, ниндидер аеруча нечкә хисләр белән сөйләде.* Г.Әпсәләмов. *Безнең чиксез кадерле кунагыбыз Гөлли Арслановна.* А.Гыйләҗев

4) Бик күп, бик зур, бик озын. *Кешенең гомере чиксез түгел бит.* А.Гыйләҗев. *Ир-ат нәфесе чиксез, яңа сылуларга ымсынмыйча калмас.* В.Имамов. *Чем-кара зур күзләреннән Чиксез йолдыз түгелә.* Б.Ибраһим

5) Кирәгеннән артык дәвам иткән, чамасыз зур, озын. *Гөлүсле кадрлар, чиксез сериал кебек, бер-бер артлы тезелә генә.* Г.Әдһәмова

6) *мат.* Кайсыдыр элементлары, берәмлекләренең саны чикләнмәгән. *Хәер, табигатькә һәм дә яшәешкә тырышып өйрәнеп, җентекләп, нигезләп бәя бирсәк, математикадагы чиксез вакланмаларны да искә алсак, без чиксезлекнең әлеге ике очракта һәрхәлдә закончалыгына, моны төптән үк аңлап җиткермәсәк тә, якынча булса да төшенербез.* М.Хуҗин. *Чиксез күплек. Чиксез тапкырчыгыш*

**2.** *рәв. мәгъ.* Бик күпкә, бик нык, гадәттән тыш булганча. *Иртәнге кояшны бергә каршылавыбызга чиксез куанган идек без.* Г.Госман. *Андый әсәрдә шаяртып яки мәсхәрәләп көлү кешенең (яки күренешнең) үзенчәлекле сыйфатларын бозып-үзгәртеп, чиксез арттырып бирү рәвешендә эшләнә.* А.Әхмәдуллин. *Әйе, мин барып кергәндә, Наилә чиксез борчылган иде.* А.Гыйләҗев

**ЧИКСЕ́З-КЫРЫЙСЫЗ** *с. к.* **очсыз-кырыйсыз**. *Бу күк чиксез-кырыйсыз, анда – бар да: Бәхет, җәннәт, фәрештә, анда – Алла.* М.Фәйзи. *Тирәякта чиксез-кырыйсыз чүлләр икән, анда чишмәләр дә челтерәми, чыкны*

*яфрагына кундырып, егетне сыйларга үләннәр дә үсми икән.* М.Хуҗин

**ЧИКСЕ́ЗЛЕК** *и.* 1) Күз күреме җитмәслек киңлек. *Ул да булмады, ярсыган бия, мескен, кешнәп, юлдан читкә тайпылды, янда гына үскән куе арышларны таптап, каядыр чиксезлеккә томырылды.* В.Имамов.

2) Пространствоның чиксез булу күренеше. *Чын галим – биологмы, физикмы яки математикмы ул – әйләнә-тирә дөньяның чиксезлегенә, дөньядагы тәртипнең искиткеч оешканлыгына, максатчанлыгына, анда мәгънәсез бер генә нәрсәнең дә булмавына торган саен ныграк ышана.* А.Тимергалин

3) Бик күп, бик зур булу; күплек; зурлык. *Ул бичара Галимәнең сөйләүләре, көлүләре, кузгалыш вә йөрешләре – һәрбере аның шатлыгының чиксезлегеннән хәбәр бирәләр иде.* Г.Ибраһимов. *Сүбәдәй императорга Европадагы кенәзлекләрнең таркау булуы, андагы байлыкларның чиксезлеге турында сөйләгәндер.* А.Хәсәнов

4) *күч.* Тирәнлек, байлык, муллык (хис һ.б. тур.). *Яшәү тәме – Хисләрем чиксезлеге.* М.Шабаев

4) *күч.* Күк, галәм. *Кеше аңы машиналар тапты, Чиксезлеккә, күккә юл ачты. Табигатьнең кануннарын ватты, Йолдыз сугышлары кузгатты.* К.Булатова

5) *күч.* Үлемнән соң була торган дип фараз ителә торган икенче дөнья. *Бу – аның мәңгелектән килеп, чиксезлеккә китеп бару сәфәрендәге бер тукталышы кына!* Н.Гамбәр

**ЧИКСЕ́З-ЧАМАСЫЗ** *с.* Бик тә, әйтеп бетергесез дәрәҗәдә. *Моңарчы кызыклы киноларда гына күреп гадәтләнгән галиҗәнап корольнең гап-гади кеше төсле татлы пирожный ашап, баллы су чөмереп утыруын күрү чиксез-чамасыз кызык иде!* А.Гыйләҗев

**ЧИКТӘШ** *с.* 1) Чиге уртак, янәшә урнашкан, күрше. *Күрше ихата белән чиктәш койма.* Л.Лерон. *Бу очракта аерым этносның характеристикасы, аның иҗтимагый үсешенең үзенчәлекләре үзләре генә түгел, ә күп гасырлар чиктәш яки уртак территориядә үзара тыгыз бәйләнештә яшәүче халыклар системасында карала.* Б.Хәмидуллин. *Ләкин ике бакча арасын бүлеп үскән чиктәш карлыганнар өлгереп, кыяр-помидорлар өч литрлы банкаларга тутырыла башлаган дәвердә көтелмәгән бер хәл килеп чыкты.* Д.Гыйсметдин

2) Берәр сыйфатка якын булган, шуңа керешеп китә торган. *Мескенлек белән чиктәш оялчанлыктан да арынырга вакыт.* Р.Юныс

3) *мат.* Кырлары уртак, икенче кырлары бер туры сызык төзи торган. *Чиктәш почмаклар*

4) *махс.* Чик хәлендәге. *Хәзерге сәхнә әдәбиятында яшәеш каршылыкларында адашып, югалып калган кешенең сызлануга, аңсызлыкка бәйле чиктәш халәтен чагылдыру белән дә очрашабыз.* Ә.Закирҗанов. *Шуларны аңлау хәленә герой чиктәш мизгелдә килә ---.* Л.Надыршина

**ЧИКТӘШЛЕК** *и.* Чиктәш булу, янәшәлек; күршелек. *Әдәбиятта юрт татарлары белән казакъларның (көнбатыш казакъларның) багланышлары чиктәшлек шартларында гына булган.* Милли-мәдәни мирасыбыз: Әстерхан татарлары

**ЧИКТӘШЛЕ́К ИТҮ** *ф.* Чиктәш булу. *– Буш Русия белән халык шыплап тулган Кытай чиктәшлек иткәнлектән, безнең территория киләчәктә бүгенге хәлендә калмаячак, – ди ул.* Татарстан яшьләре

**ЧИК-ЧАМА** *и.* 1) Берәр нәрсәнең якынча күләме. *Дөнья зур ул, җирнең чиге-чамасы юк, өч көндә әнә күпме җирләр уздык.* А.Гыйләҗев. *Хыялларның чиге-чамасы юк иде.* А.Гыймадиев

2) Эш-гамәлләрдә, үзен тотуда һ.б.ш.да сакланган шартлы чик, тәрбиялелек, тоемлау, зәвык, такт. *Тел – үтә нечкә, нәфис нәрсә, монда чик-чаманы белү аеруча мөһим.* А.Тимергалин. *Әлбәттә, гаҗәпләнүнең чик-чамасы булмады.* А.Гыймадиев

◊ **Чик-чама белмәү** Эштә, сүздә, алдауда һ.б.ш.да артыгын кылану

**ЧИ́К-ЧИК** *иярт.* 1) Чыпчыклар сайраганны белдерә. *– Син нәрсә, фил-чик. Чирик. Чик-чик. Хәзер без чыпчыклар янына барабыз! – дип чыркылдаган чыпчык.* А.Мингалимова

2) Бер төр җайланмаларда, механизмнарда кайбер өлешләре тигез генә хәрәкәтләнгәндә ишетелгән тавышны белдерә

**ЧИ́К-ЧИК ИТҮ** *ф.* Чик-чик килгән тавыш чыгару. *Эчендәге акыллы детальләре чик-чик итеп, тик-тик итеп киңәшә башладылар.* Г.Афзал

**ЧИ́К-ЧИК КИЛҮ** *ф. к.* **чик-чик итү**

**ЧИКЫЛДАТУ** *ф. йөкл. юн. к.* **чикылдау**

**ЧИКЫЛДАТЫП** *рәв.* Йөзенә бәреп, тутырып. *Туры әйткән туганына ярамаган, диләр бит, кеше йөзенә ничек чикылдатып әйтәсең.* А.Алиш

**ЧИКЫЛДА́У** *ф.* 1) Кайбер җайланмалар, кораллар хәрәкәткә килгәндә, чикы-чикы сыман кискен тавыш чыгару. *Менә кызлар эшкә тотынды. Кайчы чикылдаган тавыш, машиналар гөрелдәве...* А.Вергазов. *--- аның атабабасыннан калган кара туфраклы бодай җирләрен, бер шагыйрь әйтмешли, чикылдап, үкереп торган шау-шулы тимерчелек баскан.* Казан утлары

2) Чинау, чыелдау (кайбер хайваннар тур.). *Тик пычагым да чыкмый: әле кәҗә бәтие елый, әле бәләкәй генә чучка малае чикылдый.* Ш.Маннур. *– Санарга өйрәнмәдем әле, – дип чикылдады тычкан.* Л.Лерон. *Күрше фатирда көннәр буе көчек чикылдый, балаларга йокларга бирми.* Ватаным Татарстан

3) Кайбер кошлар, бөҗәкләр чыркылдау, чыелдау. *Бүгенге чикерткә кичәге чикерткәне чикылдарга өйрәткән.* Мәкаль. *Агач башында ике козгын карылдый, чыпчыклар чикылдый.* Р.Кәрами. *Тилгән тырнагында көзге чебеш ничек чикылдаса, мин дә шулай тырмашырга әзер идем.* Ф.Яхин

4) Бик югары яисә яңгыравык тавыш белән сөйләү, чәрелдәү. *– Кунаклар, кунаклар, – дип чикылдады Луиза.* А.Гыйләҗев. *Әмма кайдандыр аның әти-әниләре килеп җиттеләр, Гөлйөзем әбигә ачу белән чикылдап ташлана, һөҗүм итә башладылар.* Ф.Яхин

5) Чыркылдап көлү. *--- ә зал хахылдый, аяк тибә, чикылдый, сызгыра, кыскасы – бөтен кеше шат, бәхетле иде.* М.Мәһдиев. *Кыз, чикылдап көлә-көлә, күлмәк сәдәфләрен ычкындырды, шәрә күкрәкләре ачылып китте.* З.Хөснияр

◊ **Чикылдап торган** 1) Чын; төптөгәл, койган да куйган. *Төс-бит тә алай чикылдап торган чибәр түгел.* В.Нуруллин. *Ошамый бу егет миңа. Чикылдап торган анархист.* А.Гыйләҗев. *«Тәрҗемәи хәлем»дә автор чикылдаган фәлсәфи мәкаләләр язуы турында әйтә.* Ф.Сафиуллина; 2) Яңгыравыклы. *Халык арасында да әле аннан, әле моннан: «Кодагый, дим», «Кара, кодача», «Дусым апай», «Тудык җиңги» дигән шикелле чикылдап тора торган сүзләр ишетеләләр иде.* Ф.Әмирхан

**Чикылдап алу** Берара, бераз гына чикылдау. *Поездның йөреше акрыная төште, көпчәкләр чикылдап алды ---.* Р.Мирхәйдәров. *Иске «ПАЗ» автобусы яман гына чайкала башлады. Әле бер*

*якка, әле икенче якка авышкан саен, аның әллә кайсы төшләре чикылдап ала, яман шыгырдый.* Ф.Имамов

**Чикылдап тору** Әледән-әле чикылдау; әле чикылдау

**Чикылдап утыру** *сөйл. к.* **чикылдап тору**. *Комарланып, ике куллап актарына торгач, чүп-чар арасында чикылдап утырган кесә телефонын эзләп тапты.* Р.Низамиев

**Чикылдый башлау** Чикылдарга тотыну. --- *Канәгать бел, чүлмәк кызыл булырга тиеш! – капкачын күтәрде, калак тавышлары чыгарып, тагын да чупылдый, чикылдый башлады.* А.Хәлим

**ЧИКЫЛДЫК** *с.* **1.** Чикылдый торган. *Манара очы тирәсендә элек әрсез каргалар, чикылдык чәүкәләр еш кайнаша иде, хәзер күренмиләр.* Р.Низамиев.

**2.** *и. мәгъ.* Чикы-чикы килгән кем яки нәрсә. *Кем тәкә, чикылдык, минме?* Л.Лерон. *– Кара, әле генә монда иде, кая олакты бу чикылдык? – дип уйлады ул, гаҗәпләнеп.* А.Гыймадиев

**ЧИ́КЫ-МИКЫ** *иярт. к.* **черик-черик**. *Минем түбәдә җим саклаган карга кебек утырганны күреп чикы-микы килгән малайларга йодрык болгадым.* Р.Газиз

**ЧИ́КЫ-ЧАКЫ** *иярт.* Саескан чикылдаган тавышны белдерә

**ЧИ́КЫ-ЧАКЫ КИЛҮ** *ф.* Яңгыравык өзек-өзек тавыш чыгару. *Башта Биктаһирны күргәч чикы-чакы килгән саесканны күзәтте.* Н.Әхмәдиев

**ЧИ́КЫ-ЧИКЫ** *иярт.* 1) Көлү тавышын белдерә. *– Бирегә халык бик өркәк, катырак кычкырсаң, артларына да утыралар, – дип, чикы-чикы көлә-көлә мактанышты, куанышты якташлар үзләре генә калган чакларда...* Р.Зарипов

2) Чикылдаган, шундый авазлар күп булган. *Алар гына белә шул чикы-чикы телләрен*! Р.Гаязетдин

**ЧИ́КЫ-ЧИКЫ ИТҮ** *ф.* Чикылдау

**ЧИ́КЫ-ЧИКЫ КИЛҮ** *ф. к.* **чикы-чикы итү**

**ЧИЛӘГӘ** *и. фар. бот.* Урта Азия ягында иртә өлгерешле йөзем сорты; шул сорттагы йөзем

**ЧИЛӘК** *и.* 1) Су яки башка сыеклыклар, шулай ук бөртеклеләрне, яшелчә, җиләк-җимеш һ.б.ш.ны салу өчен дугасыман саплы савыт. *Булышырга шөпшәләр дә килеп җитәр, чиләк эчендәге балың минут эчендә бетәр.* А.Алиш. *Дүрт йөз-биш йөз граммлы скумбрияләр белән чиләкләре тиз арада тулды.* А.Хәсәнов

2) Саннардан соң: сыек яки бөртекле матдәләрнең күләме, үлчәве. *Әхмәд Ясәви төрбәсендә тагы бер уникаль нәрсә бар, ул да булса Тимерләң әмере белән төрбәнең үзәк залына --- куелган 600 чиләк сыешлы бакыр (бронза) казан.* А.Тимергалин. *Сүзен сөйләгән арада бер чиләк бәрәңге тутырырга өлгергән Сания койма буеннан арыш капчыгын алып килде ---.* А.Әхмәтгалиева

**ЧИЛӘКЛӘП** *рәв.* 1) Чиләк белән, чиләкләр ярдәмендә. *Арбаны яр кырыена куеп, яр астыннан суны яртышар чиләкләп ташып, фляганы тутырганчы гына да дөнья хәтле вакыт үткән булып чыкты.* В.Нуруллин. *Мәгәр сөйләүгә күчкәч, һәр кешенең хәтере, коедан чиләкләп тарткан су шикелле, үзенә отышлы хәлләрне генә сайлап ала бит.* В.Имамов

2) Чама белән бер чиләк. *Җиләк чиләкләп булырга тиеш*

3) Чиләк исәбе белән. *Чиләкләп санау*

4) *күч.* Күп итеп. *Чинау тагы башлана, күз яше чиләкләп ага.* Г.Исхакый. *Елга порты янында чиләкләп тоталар икән [балыкны].* А.Гадел. *Чиләкләп эчкәне күренеп тора иде авылдашының, йөз-кыяфәте шактый таушалган.* З.Хөснияр

◊ **Чиләкләп кою** Яңгыр бик көчле яву. *Чиләкләп яңгыр коя башлады.* М.Мәһдиев. *Берничә көн туктамый чиләкләп койганнан соң, буада су күзгә күренеп артты.* К.Тәхау. **Чиләкләп ору** *к.* **чиләкләп кою**. *Сирәк сибәләп кенә тотына да, туктап тын алгач, чиләкләп ора башлый.* М.Хуҗин

**ЧИЛӘКЛЕК** *с.* **1.** 1) Чиләк ясарга яраклы, чиләк ясарга дип билгеләнгән. *Чиләклек калай*

2) Сыйдырышлылыгы билгеле сандагы чиләккә тигез булган. *Шаулап, пошкырып торган ярты чиләклек самаварны өстәлгә утырткannan соң, ул ашханәдән чынаяклар, пәрәмәчләр, казылык кебек нәрсәләр ташый башлады.* Г.Мөхәммәдова

**2.** *и. мәгъ.* Чиләк ясарга яраклы, чиләк ясарга дип билгеләнгән материал. *Чиләклек әзерләп кую*

**ЧИЛӘНДЕРҮ** *ф.* 1) Нәрсә дә булса кырып, ышкылып, тәндә җәрәхәт калдыру, тәннең тиресен суйдыру. *Нәкъ шушы язны, мин, култык асларымны чиләндереп, мыш-мыш килә-килә корсет киеп йөргән язны, сугыш бетте.* Р.Төхфәтуллин. *Сыныкка сылтавы табылып тора: я берәр байтал аягын аксата, я түшен чиләндерә...* Р.Камал

2) *күч.* Интектерү, җәфалау; газаплау. *Гомеренең азагына тикле ул аны указсыз килеш чиләндерәчәк.* Г.Ахунов

**Чиләндерә башлау** Чиләндерү билгеләре күренү

**Чиләндереп бетерү** Бик нык чиләндерү. *[Сөләйман] --- тезе турысындагы кесәсенә башы белән диярлек кереп китеп, кәгазь чыгара, аны атның ыңгырчак кырып чиләндереп бетергән җиренә җыелган вак чебеннәргә чәпәп алгач, миңа суза ---.* Ә.Гаффар. *Агач өстәл кырында чырае зәңгәрләнеп каткан оныгы Әминә исә ачлыктан бертуктаусыз бармагын суырып, чиләндереп бетергән.* Ватаным Татарстан

**Чиләндереп тору** Әледән-әле, туктаусыз чиләндерү

**ЧИЛӘНҮ** *ф.* 1) Нәрсә дә булса кырудан, тиюдән, ышкылудан тәндә чи җәрәхәт барлыкка килү, тәннең тиресе суелу. *Бөтен ботларым, аркаларым чиләнеп яраланды.* Г.Ибраһимов. *Әби биргән дәвалар килештеме, императорлар өчен чыгарылган китапта күрсәтелгән үләннәрнең шифасы тидеме, сабыйның тәнендәге чиләнеп торган тимрәү башта кипте, аннары алар әкрен-әкрен генә кубып төшә башлады.* Ф.Абдуллин

2) *күч.* Авырлык белән эшләү, эшләп җәфалану; интегү. *Әйтик, анда ни дип әле мин чиләнергә тиеш?* А.Хәсәнов. *Гарифҗан, Сабирҗан абзыкайларына хатны инде латин имласында Әхмәтҗан абзыйлары язып чиләнә иде.* А.Хәлим

**Чиләнә бару** Торган саен ныграк чиләнү. *Аларны ничек кенә дәваласаң да кимеми, киресенчә, үсә, чиләнә бара.* И.Сиражи

**Чиләнә башлау** Чиләнергә тотыну

**Чиләнеп алу** Бераз чиләнү. *Куләйнең кран-балкасы белән бераз чиләнеп алырга туры килде.* Җ.Юныс. *Җәйге сменада шундый «авыр»ларның берсе белән бераз чиләнеп алган идек.* Ватаным Татарстан

**Чиләнеп бетү** Бик нык чиләнү. *Аның ялан аягы бик нык яраланган, чиләнеп беткән, өстенә кигән күлмәге дә әллә ничә урыннан ертылган.* Г.Кутуй. *Ул аларны көч-хәл белән сала, кабарып, чиләнеп беткән аякларын кул бармаклары белән капшап, башын селкә.* Г.Әпсәләмов

**Чиләнеп йөрү** Озак вакытлар чиләнү. --- *хисапчы булып та эшли алам, нигә мин, шул тикле зур җаваплылыкны үз өстемә алып, җан тынычлыгымны югалтып, көн-төн чиләнеп йөрергә*

*тиеш әле, дип уйлый идем.* В.Нуруллин. *– Ни дип чиләнеп йөргән булам соң? Ни тырышкан безнең Азатны да китәргә мәҗбүр иттеләр бит! – дип, кычкырып диярлек әйтеп куйды.* Н.Көбәш

**Чиләнеп тору** Әле чиләнгән хәлдә булу; гел чиләнү. *Хәле бетеп, герне ташлагач, уч төбе кабарып чыга, аннан тиресе кубып, чиләнеп тора.* Р.Кәрами

**Чиләнеп чыгу** Тулысынча чиләнү. *Чиләкләп койган яңгыр давылыннан аткайларның муеннары һәм сыртлары гел чиләнеп чыкты, ташлы тау сыртларын үткән чакта, меңәрләгән арбаларны ватып бетерделәр.* В.Имамов. *Кулларым иңбашымнан суырылып чыгарлык булып тартылды, уч төпләрем әллә тагын чиләнеп чыкты, шабыр тиргә баттым.* Ф.Садриев

**Чиләнеп яту** *сөйл. к.* **чиләнеп тору**. *Хатыны, ике баласы белән шунда бер бүлмәле бәләкәй генә фатирда чиләнеп ятса ята, әмма авылга алты почмаклы, болын хәтле өйгә кайтасы килми.* В.Нуруллин. *Синең белән мин шул «ниен» тапмаганга чиләнеп ятабыз, мең ярым белән ияк сыпырып калабыз.* А.Гыйләҗев

**ЧИЛӘТӘ** *рәв.* Чи килеш, пешермичә. *Мин Гөлгенә абызның чиләтә куырган бәрәңгесен үлеп ярата идем.* Г.Әпсәләмов

**ЧИЛӘТҮ** *ф. сөйл. к.* **чиләндерү**. *Менә халыкны тагын да шул боярлар кулына биреп, аркаларын бераз чиләтсәң, бик белерләр иде.* М.Гафури

**ЧИЛЕК** *и.* 1) Чи булу сыйфаты. *Ипинең чилеге күренеп тора*

2) *күч.* Наданлык, культурасызлык; тар карашлылык. *Мине шул яшь вакыттагы чилегем, куркаклыгым, мәхәббәткә артымны куеп, кояштан күләгә якка таба йөгерүем һәм аннары Маһирәнең күз яшьләре өчен болай җәзалыйсың булыр.* Ф.Хөсни

3) *күч.* Эшләнеп җитмәгән булу, сыйфатсызлык, эшнең түбән сыйфаты. *Язманың чилеге*

**ЧИЛЕ́-ПЕШЛЕ** *с.* 1) Пешеп җитмәгән, пешәр-пешмәс. *Шул чор Европа кешесенә һуннар чиле-пешле ит белән туенучы вәхшиләр булып күренгәннәр.* Р.Фәхретдинов. *Тозлы аш та, чиле-пешле ботка да кәефләрен боза алмады.* Р.Габделхакова

2) Өлгереп җитмәгән. *Бу урынны авыл халкы яхшы белгәнгә, киләләр дә чиле-пешле җиләкләрне Шәмсия килгәнче җыеп та китәләр.* Г.Исхакова

3) *күч.* Начар сыйфатлы, түбән дәрәҗәдә булган. *Шундый олы әдипкә чиле-пешле хат язарга буламы?!* И.Салахов. *Чиле-пешле такмак язарга өйрәнү өчен, университетта суган суы суырып, биш ел гомер уздырып, кием туздырып, эт өрдереп, кеше көлдереп йөрүнең бер дә хаҗәте юк.* Г.Афзал // Тиешле сыйфатларга ия булмаган. *Байгыш бит ул Исхак абый! Чиле-пешле егет!* А.Гыйләҗев. *Чиле-пешле актёр булып йөрисең?* Г.Каюмов

◊ **Чиле-пешле арыш кабартмасы** *к.* **арыш кабартмасы**. *Чиле-пешле арыш кабартмасына тап буласымны белсәм... валлаһи, Мәхмүт-Мудрыйга чыгар идем!* А.Гыйләҗев

**ЧИ́ЛИ** *и. ацтек* Кызыл һәм кузаклы борычның иң яндыра торган кайбер сортларының гомуми исеме. *Әйттем бит, кагылма, дип, борычның да иң зәһәре, чили борычы бит ул.* Безнең гәҗит. *Гөлҗимеш, сырганак, болгар борычы, кара карлыган, киви, чили борычы, брюссель кәбестәсе, брокколи, әфлисун, лимон, шпинат – менә С витаминлы ризыклар.* Байрак

**ЧИ́ЛИЛЫ** *и.* Чили кешесе; Чилида туып үскән, шунда яшәгән кеше

**ЧИЛИМ** *и. бот.* Батманчыклар семьялыгыннан, гадәттә, күлләрдә үсә һәм кара коңгырт төстәге бер чикләвеге була торган берьеллык үсемлек; су чикләвеге; *русчасы:* **рогульник плавающий**. *Чилим (су чикләвеге) – бүгенге көндә очрый торган сирәк культураларның берсе.* Мәйдан

**ЧИЛЧӘ** *и. диал.* 1) Сөңге башагы, сөңге очлыгы, штык

2) *к.* **тәтәл**

**ЧИЛЫК** *и. к.* **челек**. *Тау бите хуш исле үлән-чәчәкләр белән түшәлгән. Аның өстенә гөлҗимеш, чилык, ногыт куаклары.* Г.Кашшаф

**ЧИМАЛ** *и.* 1) Соңыннан сәнәгатьтә әзер продукция җитештерү өчен китә торган, табылган яки эшләп чыгарылган материал. *Сабирҗан андагы күкәй бәяләре белән, чыпта, чимал кебек нәрсәләрне кайдан китерүләре, сәүдә яклары белән дә кызыксынды.* М.Галәү. *Казах-кыргыз далаларыннан чимал җыю өчен, әлбәттә, алар белән аралашырлык сәләте булган татарлар сәүдә эшен җанландыру буенча беренче урында торалар.* М.Мәһдиев

2) *күч.* Әзер булмаган, әле эшкәртелергә тиешле нәрсә. *Ә дүртенче сандагы шигырьләр бәйләме исә шагыйрьнең куен дәфтәрендәге шигъри чималны гына хәтерләтә.* М.Шабаев

**ЧИН** I *и. рус иск.* 1) 1917 елга кадәрге Россиядә: ранглар табеле буенча дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренә һәм гаскәриләргә бирелә торган дәрәҗә, исем. *Гәзитәләр тагы баллар хакында, генералларның чин алулары хакында яза башлады...* Г.Исхакый // Гомумән хәрби дәрәҗә, исем. *Кырык беренче елдан алып соңгы көненә кадәр сугышта булган, өч медаль тагып, лейтенант чины алып кайткан егет иде ул.* В.Нуруллин

2) Кешенең хезмәт баскычындагы урынын күрсәткән исем. *Без бу җәмгыятьтә нindidер югары урын, чин, байлыкка ия түгелләр.* Д.Салихов. *Үсәсегез, чиннан чинга күтәреләсегез килмимени?* А.Хәлим

3) *күч.* Дәрәҗә; абруй. *Кешедән дә өстенрәк чин юк ул, җанкисәгем.* А.Гыйләҗев

**ЧИН** II *и. иск.* Кытай. *Дәгъвәтне гарәп, төрек, урду, чин, япон телләрендә алып бара.* Г.Гомәр. *Чиннәр элеккечә үк сугыш-орышларга йөз тотмыйча яши ---.* В.Имамов

**ЧИНАВЫК** *с.* Чиный торган, ачы яңгыравыклы. *Хәсәнҗан «солдат»ның чинавык нечкә тавыш белән «Ай, дубинушка»ны җырлап җибәрүе иң тантаналы моментның башлангычы булды.* Ш.Камал

**ЧИНАР** *и. фар. бот.* Платанчалар семьялыгыннан соры яшел кайрылы, киң яфраклы бик зур агач; һинд артышы, платан. *Бер тәрәзәмнән бугазның иң матур бизәкләнгән җирләре, чинар, сәрви, кедра, юкә агачлары белән хәтфәләнгән таулары арасыннан солтан Фатихның кальгасы --- [күренә].* Г.Исхакый. *Иелде карт чинар, башын түбән салды, Казак төсле сагышлы тын уйга калды.* М.Җәлил

**ЧИНА́Р ЧЫПЧЫГЫ** *и.* Тау чыпчыгычалар семьялыгыннан зәйтүн яшел төсендәрәк кыска койрыклы кош. *Яз хәбәрчеләре – кара каргалар, чинар чыпчыклары да күренә башлады.* Шәһри Казан

**ЧИНА́У** *ф.* 1) Нечкә ачы тавыш чыгарып кычкыру, шыңшу (дуңгыз, эт һ.б.ш. тур.). *Тәнәкә тибә, көчек чиный, әмма барыбер иярә.* М.Әмирханов. *Бүре балалары инде чинамыйлар, ырылдамыйлар да.* Г.Гыйльманов

2) *сөйл.* Нечкә ачы тавыш белән сөйләү, әйтү, кычкыру. *– Ходаем, мулла абзый янып үлә-ә, коткарыгыз! – дип чи-*

*ный хатыннар.* Р.Батулла. – *Нәрсә беләсең? – дип чинады хатыны.* Аманулла

3) *күч.* Нечкә ачы тавыш чыгару (җансыз предметлар тур.). *Беренче бомбаларның ачы тавыш белән чинап төшүләре ишетелде.* Г.Әпсәләмов. *Әмма снарядлар һаман оча, бомбалар сызгыра, катюшалар чиный.* И.Хуҗин. *Кайдадыр барлык тавышларны басып, колакны ярып, түгәрәк пычкы чиный.* Д.Каюмова

**Чинап алу** Бераз, берара чинау. *Ләкин Акъяр авылы җилләр үзгәрә торган бер ноктада утыргангамы, аңа җитәрәк давыл бер котырынып, сызгырынып, чинап алды да көн урталарына таба тагын юнәлешен үзгәртте.* Г.Әпсәләмов. *Кемдер сызлана, ыңгыраша, хәтта чинап ала.* Ә.Моталлапов

**Чинап җибәрү** Көтмәгәндә чинау. *Ат кушаяклап алга ыргылды, анымоны сизенмәгән Гыйбадулла дыйк итеп арбага ауды, яман чинап җибәрде, без, көлә-көлә, арбаны юлга чыгардык.* А.Гыйләҗев. *Колагын я тәпиен тешләткәне шундук бөтен урманга шар ярып чинап җибәрә.* А.Хәсәнов

**Чинап кую** Бер тапкыр, аз гына чинау. *Кинәт Уйнак нәрсәдәндер сискәнеп сикереп торды, нечкә генә итеп чинап куйды.* М.Маликова. *Иләмсез козгын аларның бердәнбер калган киртә баганасына утырган, аннан нәрсәнедер йолка, тегесе бирешергә теләми, думбра-саз кылы шикелле тартылып, чинап куя.* Ф.Яхин

**Чинап тору** Даими чинау; әле чинау. *Ләкин Миңнулла да шуннан ары кизәнмәде, әйләнә-тирәдән бала-чага таралышкач, бите янында чинап торган овчаркасының муенын кочаклады да үкереп елый башлады.* М.Мәһдиев

**Чиный бару** Торган саен ныграк чинау. *Тычканның йоны чыккан саен чиный бара, ди.* Мәкаль

**Чиный башлау** Чинарга тотыну. *Без өстенә ташлангач, дуңгыздан яман чиный башлады.* Г.Әпсәләмов. *Эт чиный башлый.* А.Хәмзин

**ЧИНЛЫ** *с.* Билгеле бер чины булган. *Шулай көтеп утырганда, ике офицер ияртеп, юан гәүдәле олы чинлы бер хәрби кеше – начальник пәйда булды.* Р.Кәрами. *XVII–XVIII гасырларда хакимият контораларында күбесенчә тылмачлык итүче, йомыш-юлларга йөртелүче түбән чинлы татар кешеләре.* А.Тимергалин

**ЧИННЕК** *и. рус диал.* 1) Печәнлек. *Ишегалдында саман кирпечтән салынган салам түбәле сарай һәм тактадан эшләнгән, түбәсенә толь ябылган чиннек, аның белән сарай арасында туры лапас, аңа эскертләп хуш исле урман печәне һәм әле яшеллеген югалтмаган бәрәңге сабаклары өелгән.* Р.Кәрами

2) Келәт, амбар

3) Өстенә печән өелә торган, асты буш булган корылма, лапас. *Каралтыкура рәтендә кырдагы әвен һәм зуратлардан кайтарып көлтә сугу өчен өсте ябулы аран, кыш көне арбатарантаслар куела, миллек эленә, утын өелә торган чиннекләр, күчеп нигезләнергә әмер генә көткән өр-яңа нарат бура – бары да бар.* В.Имамов

**ЧИНО́ВНИК** *и. рус* 1) Дәүләт хезмәткәре; түрә, мәэмүр. *Әгәр инде ихтыярсыздан ул сүзләр аның күңеленә килсәләр, хәзер үк әлеге пенснелы салкын чиновник күз алдына килеп баса...* Ә.Еники. *Аның свитасында земский начальник, земский доктор, исправник, мәгариф инспекторы һәм башка чиновниклар була.* М.Мәһдиев

2) Үз эшен бик салкын башкара торган, эшенә үтә формаль караучы урындагы кеше; бюрократ. *Илгә – без бер! Безгә – Россия бер! Булма ахмак, чиновник, тәкәббер!* Ә.Гадел. *Хакимият башлыгын күз алдына ниндидер чиновник итеп китерәләр.* Р.Вәлиев

**ЧИНО́ВНИКЛАРЧА** *рәв.* **1.** 1) Чиновник кебек, түрәләрчә. *Шундыйрак тәрбия алган балаларга карата борынгы чиновникларча ваемсыз түгел, ә аерата кешелекле, игътибарлырак булуларын үтенде.* Ш.Шәйдуллин. *Чиновниклар турындагы бу закон чиновникларча язылган, бер утыруда аңларлык түгел.* Татарстан яшьләре

2) Формаль рәвештә, коры итеп; бюрократларча. *Чиновникларча эш итү*

**2.** *с. мәгъ.* 1) Чиновникларга хас булган

2) Формаль, коры, эре, тәкәббер

**ЧИНО́ВНИКЛЫК** *и.* 1) Дәүләт хезмәтендә эшләү, чиновник (*1 мәгъ.*) булу. *Әгәр яшьрәк чакта, алданып, берәр чиновниклык юлыннан китсәм, бәлки, күптән муеным сынган булыр иде.* Р.Вәлиев. *Бу чиновниклык эше минем язучылыгымны харап итә, ахырысы.* Казан утлары

2) *күч.* Үтә формаль, коры эш итү рәвеше, бюрократлык. *Гомумән, аңарда безнең җәмгыятьнең канында яткан бюрократизм, чиновниклык юк.* Р.Вәлиев

**ЧИҢЛӘ́Ү** *ф. сөйл.* Бишташ уйнаганда, уенны кем башларга тиешлеген белү өчен, ташларны кул артына төшерү

**ЧИП-** *кис.* [ч] авазына башланган кайбер сыйфатларның артыклык дәрәҗәсен ясый торган алкисәкчә. *Абыстай янында кара кашлы, зәңгәр күзле, зифа буйлы, карап туймаслык чип-чибәр татар кызы басып тора иде.* Г.Бәширов. *Әле кичәлебүгенле генә ачылып маташкан яфраклар чип-чиста, нәфис иделәр.* А.Гыйләҗев. *Утыннар – чип-чи усак.* Ф.Яхин

**ЧИП** *и. ингл.* Интеграль схема төшерелгән саф кремний пластинадан гыйбарәт кристалл; биочип. *Казанга килүгә, Фидан Чемодан ике сим карта алган, чиплар Украина кунагы вакытлыча яшәп яткан йорттагы бер ир исеменә теркәлгән.* Ф.Бәллүр // ЭХМ микропроцессорының нигезе буларак электрон деталь

**ЧИ́ПСЫ** *и. ингл.* 1) Бик юка итеп теленеп майда кыздырылган бәрәңге; бәрәңге йомычкасы. *Беренче-икенче сыйныфларда укыган чакта ук төне буе бәрәңге әрчеп чипсы ясый идем.* Ф.Тарханова. *Ул арада бармен фисташкалар, чипсылар салынган савытлар да китереп куйды.* Х.Әбделмәнов

2) Берәр җимеш, яшелчәне бик юка телеп киптереп әзерләнгән ашамлык. *Баклажан чипсысы кибеттәге бәрәңге чипсысыннан тәмлерәк була.* Акчарлак

**ЧИ́П-ЧИП** I *иярт.* **1.** Тавык чебиләренең, каз бәбкәләренең һәм башка кайбер кош балаларының тавышын белдерә. *Ай чебиләр, чебиләр, Бер дә чип-чип димиләр; Үзләре тик яталар, Мине чыелдаталар.* Ш.Галиев

**2.** *ы. функ.* Тавык чебиләрен һәм башка кайбер кош балаларын чакыру сүзе. *Чип-чип-чип... Чип-чип-чип ---. Әнә, әбекәе дә йортта бугай. Тавыкларга җим таратадыр.* Ф.Җамалетдинова

**ЧИП-ЧИП** II *и. этн.* 21 мартта балалар өйдән өйгә йөреп, хуҗаларга байлык, муллык сорап башкарылган календарь йола. *21 мартта балалар төркемтөркем булып өйдән-өйгә йөргәннәр, келәү келәгәннәр. Бу йола чип-чип дип аталган.* Р.Исхакова-Вамба

**ЧИ́П-ЧИП КИЛҮ** *ф.* Чип-чип сыман тавыш чыгару. *Чебиләрем, нәниләрем, Энҗе томшык бәбиләрем, Тик бер сүзне беләсез: Чип-чип, чип-чип киләсез.* Р.Вәлиева

**ЧИР** *и. сөйл.* 1) Берәр әгъзаның иясә әгъзаларның нормаль эшчәнлеге бозылу нәтиҗәсе; авыру; хаста, сырхау.

*Бөтен дөньяга танылган Тянь-Шань тауларыннан тау бәлзәме җыеп, төрле чирдән дәвалый иде [ул].* А.Гадел. *Бүтән берәү мондый чир эләктерсә, аның исе китмәс иде, авыру я үләр, я терелеп чыгар иде.* А.Гыйләҗев. *Чирне аны беребез дә сорап алмыйбыз.* А.Хәсәнов

2) *күч.* Кешедә, җәмгыятьтә күзәтелгән берәр тискәре күренеш, сыйфат, начар гадәт. *Ләкин дөньядагы сугыш дигән чиргә каршы бертөрле дә дару таба алмады.* А.Алиш. *Ул әнә шул үлемнән курку чире белән моннан алты ел элек минем яныма килгән иде.* А.Гыйләҗев. *Ләкин акрынлап илдә әхлак бозыла барган, атлантлар кавеме әүвәлге яхшы сыйфатларын җуйган, вөҗдан-намусны һәм игелекне оныткан, бүтәннәргә баш булырга омтылу, малга хирыслык, байлык җыю кебек яман чирләр таралган...* А.Тимергалин

**ЧИРАК** I *с. сөйл.* **1.** 1) Каты катылган, бөterelгән (җеп тур.). *Чирак җеп*

2) *күч. диал.* Җитез, өлгер, уңган. *Ул укуда да бик тырыш, эшкә дә бик уңган, чирак кыз иде.* Ш.Маннапов

**2.** *рәв мәгъ.* Каты, тыгыз итеп (эрләү, кату тур.). *Чирак эрләү*

**ЧИРАК** II *с.* Әле катып бетмәгән (боз тур.). *Кар-бураны белән кышлар җитә, Чирак бозлар Зәйне каплаган.* К.Булатова

**ЧИРАТ** *и. рус* 1) Берәр эштә, процесста билгеле бер эзлеклелек, тәртип; нәүбәт. *Безнең заводта гына ике мең кеше фатир чиратында торганда каян тапсыннар ди безгә?* А.Гыйләҗев. *Эшне чират белән эшләү* // Берәр эш эшләү яки берәр нәрсә төзүдә билгеләнгән тәртипнең бер өлеше. *Хәйрүш агай, үзең белеп өләш. Яланаяклыларга беренче чиратта бир.* А.Гыйләҗев

2) Берәр нәрсә алу, берәр эшне башкару өчен, тәртип белән берсе артыннан икенчесе торган кешеләр төркеме. *Буфетка якын килерлек түгел – чират иде.* В.Нуруллин. *Базарда ит чиратында торганда апайлар, түтәйләр сөйләшәләр иде: бер сум биш тиенгә кысыр аш – итсез аш пешерәләр икән.* Б.Рәхимова

3) Берсе артыннан икенчесе торган кешеләр төркемендә яки шулай формалаштырган эшләр тәртибендә кайсының да булса урыны; шул тәртиптә берсенең эшне башкару вакыты. – *Әйдә тизрәк, чиратым үтә юкса, – дип, театр буфеты ягына ымлады.* В.Нуруллин. *Димәк, иң зур сыйга – әле генә мичтән чыккан каз бәлешенә чират җиткән.* А.Гыйләҗев. *Шулай булгач, хәзер инде минем чиратымдыр.* В.Имамов

4) Автомат ату коралыннан берничә мәртәбә рәттән ату, шундый атыш. – *Кыска чиратлар белән генә атарга! – диде Верещагин.* Г.Әпсәләмов. *Скоба сүгенеп, аларга карап, озын чират белән атарга тотынды.* З.Зәйнуллин

◊ **Чират җитү** *к.* **чират тию**. *Аңа да кәкрәергә чират җитәр әле!* В.Имамов. **Чиратка басу** *к.* **чиратта тору**. *Ә бездә «Тукай теле сүзлеге»ннән соң, «Исхакый теле сүзлеге», «Ибраһимов теле сүзлеге» кебек белешмәләр чиратка бассын иде.* А.Тимергалин. **Чиратка салу** *этн.* Караучысы булмаган карт яки авыру кешене бөтен авыл белән тәрбиягә алу гадәте. *Кичә Саранчалар Әндереш дәдәйне исертеп екканнар да Сима түтәйне чиратка салганнар, ди.* В.Имамов. **Чиратка тезелү** *к.* **чират тору**. *Бай ир-атны аулаучы йөз миллион кыз чиратка тезелгәндә, Зәринә кебек балалы хатыннарга ни исәп тә, ни сан ди.* Г.Әдһәмова. **Чиратта тору** Алда тору, якын киләчәктә башкаруны, хәл итүне таләп итү. *Без сизәбез: Әле дошман белән Соңгы бәрелеш тора чиратта.* М.Җәлил. --- *бу профессорларыбыз әлегә әдәбиятыбызның чиратта торган ихтыяҗларын капларлык зур эшләр күрсәткәннәре юк.* Л.Җәләй. **Чираттан тыш** 1) Билгеләнгән вакыттан алда үткәрелә, чиратка куймыйча башкарыла торган. *Фабрикалары янгач, чираттан тыш ял биргәннәр үзенә.* Г.Гомәр; 2) Булганга өстәп. *Сугышны башларга маташкан гусарларны биш көн буена конюшняда, чираттан тыш, ат бугы тазартырга куярга.* З.Зәйнуллин. **Чират тию** Берәр нәрсә эшләргә мөмкинлек туу, насыйп булу; вакыт җитү. *Автомашиналарга һаман чират тигәне юк.* А.Гыйләҗев. *Өлфәт авыл советы тирәсендә борынын тартатарта бөтерелеп йөрсә дә, аңа чират тимәде.* А.Тимергалин. **Чират тору** Теләү, берәр нәрсәгә ихтыяҗ булу турында. *Элек мине мунчага, ашка чакырырга чират торалар иде.* Ф.Яруллин. *Минә дигән асыл ир-егетләр Көн-төн синең янга чират торыр...* Ш.Җиһангирова

**ЧИРАТЛАНУ** *ф. к.* **чиратлашу**. *Кешегә кайгы төрле вакытта килергә мөмкин дип, алар әнә шулай чиратланып сакта торалар.* М.Хуҗин

**ЧИРАТЛАП** *рәв.* 1) Чират белән; берсе артыннан икенчесе. *Алтын алкалы солылар, чыршы күркәсе кебек эре башаклы бодайлар, берсен берсе чиратлап, әле уңга, әле сулга җәелгәннәр.* А.Гыйләҗев

2) Алмашлап, башта берсе, аннан икенчесе. *Кайберәүләрнең апа-абыйлары, пенсиядәге әти-әниләре була, чиратлап дежур торалар.* В.Нуруллин. *Ахыр чиктә Алик мондый тәкъдим кертте: чиратлап йокларга!* А.Гыймадиев

**ЧИРАТЛАШТЫРУ** I *ф.* 1) Берсен икенчесе белән бер-бер артлы алыштыру; чиратка салу. *Шул ук вакытта бу автор Аллаһының исемен аның күп төрле башка синоним парлары белән чиратлаштыра: Хак Тәгалә, Ходай, Хода, Ходавәндә, Халикъ, Мәүлә.* И.Бәширова. *Үсемлекләр 8–10 см булгач, составында бакыр булган препаратларны чиратлаштырып сибәргә.* Арча хәбәрләре

2) Аралаштыру. *Аля-Әлфия ике телне дә яхшы белә, тик еш кына аларны чиратлаштыра яки шуның артыннан ук икенче телнең тәрҗемәсен дә кабатлый иде.* З.Хөснияр. *Кәстрүлгә ит, суган һәм лимон кисәкләрен, тәмләткечләрне чиратлаштырып тезәбез.* Әгерҗе хәбәрләре. *Кыздырыр алдыннан, шампурга ит кисәкләрен, суган, помидорны чиратлаштырып тезәргә.* Әлмәт таңнары

**Чиратлаштыра бару** *к.* **чиратлаштырып бару**. *Агымдагы тәнкыйтебез, таләпчәнлекне талантка игътибарлы мөнәсәбәт белән чиратлаштыра барып, әдәбият күренешләрен бәяләү эшенә таләпчәнрәк, объективрак төстә якын килә башлады.* Р.Мостафин

**Чиратлаштыра башлау** Чиратлаштырырга тотыну. *Бер төрле генә шөгыль туйдырмасын дип, аларны чиратлаштыра башладым.* Сөембикә

**Чиратлаштырып алу** Тиз арада чиратлаштыру; беразга чиратлаштыру. *Азакка хәтле кабатланган «ырылдаулар»ны «һ»ның «аһылдавы», «м», «н», «ң» тартыкларының «иңрәве» чиратлаштырып ала.* Р.Абдуллина

**Чиратлаштырып бару** Даими чиратлаштыру; бер-бер артлы чиратлаштыру. --- *патриотизмга дан җырлау хисләрен фәлсәфи уйлану һәм уйландырулар, хәтта сентиментализм белән дә үреп чиратлаштырып бара.* Р.Абдуллина. *Әлеге программа нигезендә кыска гына вакыт эчендә әзер материаллар ярдәмендә яңа презентация эшләргә, аерым слайдларны тиз генә төзәтергә, әзер презентациягә яңа*

*слайдлар куярга, рәсемнәрне текст һәм аңлатмалар белән чиратлаштырып барырга мөмкин.* Фән һәм тел

**Чиратлаштырып тору** Һәрвакыт, туктаусыз чиратлаштыру. *Урынын бәрәңге белән чиратлаштырып торыгыз.* Акчарлак

**ЧИРАТЛАШТЫРУ** II *и.* Бер нәрсәне икенчесе белән алыштыру күренеше. *Мәгънәдәш сүзләрне чиратлаштыруның тәртибе һәм аларның кабатлану ешлыгы төрле әдиптә үзенчә була.* И.Бәширова

**ЧИРАТЛАШУ** I *ф.* Эзлекле рәвештә яисә чират тәртибендә урнашу яки башкару, берсен икенчесе алыштыру. *Бер үк кәгазьгә бер үк карандаш белән ике-өч бала чиратлашып язалар.* Г.Әпсәләмов. *Газзәбану белән Зөлкамал көн саен чиратлашып килеп ризыкландырып тордылар.* Г.Галиева

**Чиратлаша бару** Эзлекле рәвештә туктаусыз чиратлашу. *Чиратлаша бара Көн белән Төн ---.* Ә.Рәшит

**Чиратлаша башлау** Чиратлашырга керешү. *Русча, татарча, марича җырбиюләр чиратлаша башлый, ярыштамаша бергә кушылып, мәйданга таба юл тота.* А.Вергазов

**Чиратлаша тору** Һаман чиратлашу; туктаусыз чиратлашу. *Тормышны кайчак я матрос тельняшкасы, я зебра белән чагыштыралар: ягъни юллы-юллы, кара-ак сызыклар чиратлаша тора.* Ә.Мушинский

**Чиратлашып алу** Бераз чиратлашу. *Дөрес, алар яңгырлар белән чиратлашып алачак.* Әлки хәбәрләре

**Чиратлашып бару** Эзлекле рәвештә чиратлашу; даими чиратлашу. *Шәрык архитектурасында бизәк төшерүнең үзенә генә хас мәдәни ысулы бар: анда үсемлек һәм геометрик сурәтләр чиратлашып бара, шуңа күрә аны европалылар арабескалар дип атаганнар.* Р.Фәхретдинов

**Чиратлашып китү** Чиратлашкан рәвеш алу; кинәт чиратлашу. *Аллеяның буена карасаң, чиратлашып киткән бу якты-кара басмалар ничектер сөзәк кенә күтәрелгән мәрмәр баскычны хәтерләтәләр...* Ә.Еники

**Чиратлашып тору** Туктаусыз чиратлашу. *Тыныч аралашу, сәүдә итү хәрби бәрелешләр белән чиратлашып торган.* Т.Әйди. *Көн белән төн чиратлашып тора. Яхшы-яман белән дөнья тулган.* Ф.Зыятдинова

**ЧИРАТЛАШУ** II *и.* 1) Нindидер нәрсәләрнең билгеле бер тәртиптә алмашыну күренеше. *Тормышның дәвамы буыннар чиратлашуында чагыла.* М.Хәсәнов. *Бу система буенча строфаның төзеклегең ижекләр санының тәңгәллеге, ритмик төзеклекне озын һәм кыска ижекләрнең тәртипле чиратлашуы хәл кыла.* Н.Хисамов

2) *лингв.* Билгеле бер позициядә авазларның эзлекле рәвештә алмашыну күренеше. *Бездә сузыкларның чиратлашуларын түбәндәге сүз калыплары җәдвәленнән күрергә мөмкин.* Г.Алпаров. *Арткы рәт сузыкларның алгы рәт сузыклар белән чиратлашуы сингармонизм законына буйсындырылып барлыкка килә.* Г.Шәйхиева

**ЧИРАТЛАШЫП** *рәв.* Берсе икенчесе белән алмашынып, башта берсе, аннан икенчесе. *Умарталыкны чиратлашып саклыйбыз.* А.Хәсәнов. *Т.Ялчыголның «Рисаләи Газизә» әсәрендә исә әлеге мәгънәсендә «җәмәгать» сүзе «кавем» сүзе белән чиратлашып кулланыла.* И.Бәширова

**ЧИРАТСЫЗ** *рәв.* Чират тәртибен бозып, чиратны сакламыйча, алдан кереп. *Чиратсыз билет саталар!* А.Гыйләҗев. *Болай да чиратсыз үтүчеләр белән канга батып сугышулар булды.* Г.Гомәр

**ЧИРАТТАГЫ** *с.* 1) Чиратта торган. *Танышлары күп икән абзыйның, чираттагы берничә кеше аның белән килеп күрешә, хәлен белешә.* М.Хуҗин. *Чираттагы хатыннар, ирләр тагын да яманрак шауларга, кычкырырга тотындылар.* Н.Фәттах

2) Чиратка салынган һәм алдагысыннан соң килә торган. *Чираттагы өйдә чыбыркы тотарлык исәү бала юк, --- боларга ышанып малларны тапшырсаң, кышка итсез каласыңны көт тә тор!* А.Гыйләҗев

3) Билгеле бер эзлеклелек белән үзеннән алдагысыннан соң килә, эшләнә торган. *Көн буе чираттагы номер газета эшләнде.* Г.Кутуй. *Күңелгә моңсулык өстәп, чираттагы ел да узып бара.* Н.Гыйматдинова. *Борынгы диннәрнең чираттагы баскычы – анимизм ---.* Г.Дәүләтшин

4) Билгеле вакыт үтү белән даими кабатлана торган. *Колхозның чираттагы отчёт-сайлау җыелышына әзерләнеп йөргән көннәрдә мине райкомга чакырттылар.* В.Нуруллин. *Чираттагы отпускымны иртәрәк алдым.* З.Хәким // Вакыт-вакыт, әледән-әле кабатлана торган. *– Тыңлагыз әле, малайлар, әнә ничек матур итеп улый бит! – дип, бүренең чираттагы улавын тыңлап тора башлады [Мәхмүт].* В.Нуруллин

5) Чират тәртибе белән беренче, иң якында булган, беренче торган; киләсе. *Грамматикада формаль принципка күчү уңае белән телебезнең ялганмалык үзенчәлеген, ялганмалыкның табигатен тикшерү безнең өчен чираттагы мәсьәлә булып тора.* Г.Алпаров. *Старшина ике кулын ике якка җәя биреп авызын ерды да, янына килеп баскан атка карамыйча гына, чираттагы кешене чакырды.* З.Зәйнуллин

**ЧИРАТУ** I *ф.* 1) *з.-сыз* Бераз туңдыру, катыру. *Күрәсең, төнен кар яуган да, аяк астын чиратып, җиргә ертык ак җәймә капланган.* С.Рафиков. *Аяк астын төнлә яхшы ук чираткан.* Э.Касыймов

2) Салкыннан, дулкынланудан тәндә чымырдау, калтырау, өшү барлыкка килү; өшетү. *Булат, тән чираткан күренештән арынырга теләп, чигәләрен кысты.* Ә.Гаффар. *Коры, суык җил куенга үтеп, салкынга күнекмәгән тәнне чирата.* Сөембикә

**Чиратып алу** Тиз арада яки бераз чирату. *Төнге суык чиратып алган карның һәр бөртегендә кояш нуры ялтырый.* Ә.Мушинский

**Чиратып җибәрү** Аз гына чирату. *Төнгелеккә чиратып җибәрү белән юлларын дәвам иттеләр.* Х.Галидән. *Җиргә ныклап кар ятмаса да, соңгы көннәрдә һава температурасы 0 дән түбән тәгәрәп, бераз чиратып җибәрде.* Хезмәт даны

**ЧИРАТУ** II *ф. диал.* Чирак катылган җепне сүлпәнләндереп кире кату. *[Шәлгә мамыкны] Үзем эрлим, катлыйм, чиратам, бәйлим.* Милли-мәдәни мирасыбыз: Оренбург өлкәсе татарлары

**ЧИРА́Т-ЧИРАТ** *рәв.* 1) Бер-бер артлы, чиратлашып. *Өчегез дә, мине чират-чират пропискага кертеп, өчәр бүлмәле фатир алдыгыз.* А.Гыйләҗев

2) Күп итеп; күп булып, рәт-рәт. *Тезелеп арттан кибәннәр Калмады чират-чират ---.* И.Диндаров

**ЧИРА́У** *ф.* 1) Җир яки су өсте аз гына туңу, боз элпәсе белән каплану. *Куәтле прожекторлар яктысында, иләмсез гүләгән дизельләр тавышы астында таптанып төн уздыра торгач, сизми дә калган: һава болытлардан арынып, иртәнге салкын төшкән, аяк асты чирап кипшенгән.* Җ.Рәхимов. *Бәке авызлары чираган иде, тишекләрдән полт итеп су бәреп чыкты: күптән түгел генә кузгалганнар, димәк.* М.Хуҗин

2) Замазка, алебастр кебек изелгән массалар кибә башлау, беркадәр катыру, каты хәлгә килү. *Слайм чираган инде* // Өслеге беркадәр тыгызланып, юка элпә белән каплану. *Ит чирагач ук табадан алып, газ мичәнә куярга кирәк*

3) Салкыннан, дулкынланудан тән чымырдау, калтырау, өшү, тәнгә салкын йөгерү

**Чирап бетү** Тулысынча чирау. *Хәзер таңнан чыгып китәбез, көндез әбәдкә тукталалар, зонадан китерелгән, юлда суынып, чирап беткән баланданы аяк өсте генә чүмерәбез дә тагын эшкә ябышабыз.* А.Гыйләҗев

**Чирап киту** Кинәт чирау. *Кайнар кофе чирап киткән тәнемә җылы кертеп җибәргәч, Айбулат подполковник Сафиуллинга ---- Азәрбайҗаннан –Нахчыван АССР Эчке эшләр министрлыгыннан телеграмма килүен хәбәр итте.* Т.Әйди

**Чирап кую** *к.* **чирап киту**. *Капкадан чыккач, Гәрәй кинәт чирап куйды. Ачык яр буенда һава салкыная төшкән.* С.Сабиров

**Чирап тору** Әле чирау. *Ужҗымнарда иртән кырпы-кырау, Су читләре чирап торалар.* К.Булатова. *Өскә чыккан су шунда ук чирап тора.* А.Хәсәнов

**Чирый башлау** Чирау билгеләре күренү. *[Костя] чирый башлаган замазканы озак кына кулында әвәләп, токмач кебек итеп сузды да тәрәзә ырмавына куйды.* Г.Ахунов. *Салкында басып торудан чирый башлаган аякларына җан кертергә теләп, хром итекләрен берберенә каккалап алды.* Р.Мөхәммәдиев

**ЧИРӘМ** *и.* **1.** 1) Кыска яшел үлән. *Иртәгесен яшел чирәм өстендә кырпак яуган кар сыман кырау күренде.* А.Алиш. *Койма буйларында яшел чирәм, әмма юллар тузанлы.* Г.Әпсәләмов

2) Кыска яшел үлән үскән җир. *Без бәләкәй чакта, әнә теге ак маякны күрәсеңме, шул турыга барып, чирәмдә бишташлы уйный торган идек.* А.Гыйләҗев. *Киң урам чирәмендә яңгыр сулары күлләвекләр булып җыелып тора.* М.Хуҗин

3) Туфракның үлән үсемлекләр һәм аларның тамырлары берекән өске катлавы. *Айгыр аз гына кымшанса да, тирә-якка белен кадәр чирәм кубып оча.* В.Имамов

4) Эшкәртелмәгән, бер дә сөрелмәгән җир. --- *эткәй Кысылдык башкортларыннан мәңге сабан-сука кермәгән бер җир – каты чирәм сатып алган.* Г.Ибраһимов. *Бу яклардагы җирнең чирәмен сука, сабан белән беренче булып татар игенчеләре ярган.* З.Зәйнуллин

5) Газон. *Казансу ягына брусчатка түшәү, ишегалдына чирәм чәчү кебек эшләрне көннәр җылыткач башкарырга уйлыйлар.* Шәһри Казан. *Авыл җирлеге бинасы территориясенә туфрак кертеп, яшел чирәм чәчтеләр, барлык төзелеш эшләре тәмамланугa чәчәкләр утыртырга ниятлиләр, үсентеләр әзер инде.* Авыл таңнары

**2.** *с. мәгъ.* 1) Кыска яшел үлән үскән, кыска яшел үлән баскан. *Болакның чирәм ярлары Төшләргә керә кайчак ---.* М.Сафин. *Яшел чирәм юллар Бүген инде карлы.* Л.Шәех. *Алгы якта, ямьяшел чирәм аллеяда, берничә куак үсеп утыра.* Д.Салихов

2) *күч.* Эшкәртелмәгән, сөрелмәгән. *Күкчәтау драма театры бинасында беренче чирәм җир уңышын урып җыю йомгаклары буенча җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы бара.* А.Хәлим. *Ындыр артындагы чәчүлекләрне ташлап, җәһәннәм тишегендә чирәм җирләр сөрдек.* А.Хәмзин

◊ **Чирәм җир** Фәндә аз өйрәнелгән өлкә. *Бу мәсьәлә әле чирәм җир булып кала бирә*

**ЧИРӘМЛӘНҮ** *ф. сир.* Чирәм чыгу, яшелләнү

**Чирәмләнеп бетү** Чирәм басу. *Атасының әмере буенча анасының кабере өстенә барып, яшертен, хәтта үзеннән үзе яшереп, чирәмләнеп беткән иске кабер өстенә берничә кайнар яшь тамчыларын тамызып, аның белән бәхилләште.* К.Тинчурин

**ЧИРӘМЛЕ** *с.* Чирәм үскән; чирәм баскан. *Чирәмле мәйдан уртасына урнашкан кечкенә генә кибеткә килүчеләр кичке сәгатьләрдә аеруча күбәя.* М.Галиев. *Бу – мин, синең чирәмле урамнарыңда кайчандыр ялантәпи чапкан шаян малай.* И.Диндаров

**ЧИРӘМЛЕК** *и. к.* **чирәм** (*2 мәгъ.*). *Юл дисәң юл түгел, ниндидер бер чирәмлектән бара башладык.* И.Гази. *Бу юлы, карасам, янымда гына, ямьяшел чирәмлектә бик матур, берләре чуар-чуар, берләре сап-сары тавык чебешләре йөри.* А.Хәсәнов

**ЧИРӘП** *и.* **1.** 1) *иск.* Керамик әйберләр ясарга ярый торган балчык. *Чирәптән – чүлмәк, чүпрәктән – күлмәк.* Мәкаль

2) Балчык чүлмәк; теләсә нинди керамик савыт. *Биредә борынгыдан килгән аш-су атамалары да үзе бер тарихи дөнья: күптермә, умак, куш катлама, чирәп бәлеше, чүлмәк бәлеше һ.б.* Милли-мәдәни мирасыбыз: Нижгар татарлары

3) Цемент, яндырылган балчык яисә корыч, алюминий, бакырдан буйга улаксыман батынкы итеп эшләнгән түбә ябу материалы. *Аннары, кисәктән генә бер тыкрыкка борылып, биек тимер койма артыннан күренеп торган, башын кызгылт чирәп белән япкан ике катлы таш йорт алдына килеп туктады.* А.Хәсәнов. *Күктән, болытлар арасыннан еш кына авыр бомбардировщикларның гөрелтесе иңә, хәтта бу гөрелтедән барак түбәсенең мүкләнгән чирәбе кубып төшкәли.* А.Тимергалин

**2.** *с. мәгъ.* Шундый материал белән ябылган. *Ул күперләр, тоннельләр, виадуклар – юлларда чакрым саен; кызыл чирәп түбәле өйләре гаҗәп таза, нык итеп кирпечтән, таштан салынган.* Р.Кәрами. *Әнә авылның беренче һәм әлегә бердәнбер калай чирәп түбәле йорты!..* Р.Гаязетдин

**ЧИРБИК** *и. сөйл.* Шнурлана торган озын кунычлы хатын-кыз аяк киеме. *Инде эше бетте дигәндә генә, көтелмәгәннән, аяк астыннан янә бер уңайсызлык чыкты: ак чирбиккә муафикъ калош алынмаган, ә өйдәге кәвешләр ак чирбиккә якын да килмиләр иде.* К.Тинчурин

**ЧИРЕК** *и. фар.* **1.** 1) Бөтеннең дүрттән бер өлеше. *Якынча айның чирек өлешенә туры килгән вакыт арасы атна дип атала.* А.Тимергалин. *Чирек алма ашап кем туйсын ди?* В.Имамов

2) Тиеннең дүрттән бер өлешенә тигез борынгы бакыр тәңкә. *Өстенә төлке тун кигән, мыегын тигез итеп кискән, сирәк сакаллы бу кеше прилавкада яткан калай тартмадан чирек тиен акча алып, карамыйча гына Сафага сузды.* М.Галәү

3) Сәгатьнең дүрттән бер өлеше, унбиш минут. *Сәгать 12 нче чирек булган.* Г.Камал. *Сикереп торып сәгатьләрен карасам, нибары ике тулып чирек.* М.Мәһдиев

4) *иск.* Кадакның дүрттән бер өлешенә, якынча 100 граммга тигез булган авырлык үлчәве. *Заманында зур корсаклы, Тугыз потлы кешеләр Өч чирек кара икмәкне Тәүлек буе көйшиләр.* Г.Камал. *Ярты пот он, биш кадак ит, чирек чәй, бер кадак шикәр, биш кадак күмәч алдырдым; алай да утыз тиен акча калды әле.* Г.Исхакый. *Аңа бары-*

*сы да сыя: бер кило түбә кадагы, ике кадак хәлвә, чирек такта чәй, бер банка тәрәзә буявы, өч кадак замазка, ике өтерге, чебен даруы, хатынга кәшимир яулык, малайга уенчык автомобиль...* М.Мәһдиев

5) Метрик системага кадәр борын заманнан кулланылган, чиләк сыешының дүрттән бер өлешенә тигез булган сыеклык күләмен үлчәү берәмлеге (3,1 л). *Хәзрәт белән мәзинне озатып куюга, табынга берничә чирек бал, сап-сары агач тустаганнар килеп чыкты.* Г.Бәширов // Шушы күләм сыешлы савыт, зур шешә. *Мөәззин кызы, мөәззин угылы, Анна, Шәмси, чирекләргә кымызлар тутырып, пар ат җигеп, җыеннарга йөрергә тотындылар.* Г.Исхакый. *Табыннарга аш-су килә, чирекләр белән бал килә, мәҗлес башлана.* Ә.Еники // Шундый күләмле савыттагы аракы. *Арчадан поты бер тәңкәлек ак капчыклы, кызыл пичәтле ак он да әллә ничә капчык алынды, кызыл башлы чирекләр дә, тегермән ташы тикле базар күмәче дә, куй мае, йөзем җимеше дә, бүтәннәре дә мул кайтты.* Г.Бәширов. *Малайлар печән астыннан күренеп торган чиреккә ымладылар.* Д.Гыйсметдин

6) Метрик системага кадәр борыннан кулланылып килгән, аршынның дүрттән бер өлешенә тигез булган озынлык үлчәү берәмлеге; карыш (17,775 см). *Патша кызга өч чирек җептән киндер сугып, күлмәк-ыштан тегәргә куша.* Әкият. *Авыз эштән чыгып бозылган, тел, бер чирек булыр, тышка чыгып, каралып салынып тора...* Г.Ибраһимов. *Буйга да уртача гына Ләйсирә, миннән бер чирек чамасы гына кечерәк кебек ул.* М.Вәлиев

7) Уку елының якынча өч айдан торган бер өлеше. *Чиреккә билгеләрем яхшы чыкты.* А.Гыйләҗев. *Чирек йомгакларын барлаганда күпме тыңлап тордым.* В.Имамов

8) *муз.* Бөтен нотаның дүрттән бер өлешенә тигез булган озынлыгы; *русчасы:* **четвертная**. *Җырның ноталарын карагыз: монда ике чирек бар. Бөтен нота 4 секунд яңгыраса, чирек – 1 секунд кына*

9) *геом.* Квадратның дүрттән бер өлеше; квадрант. *Чирекләр (квадрантлар) уңнан сулга таба, почмаклар тәртибе белән саналалар.* Югары математика нигезләре

**2.** *с. мәгъ.* 1) Тиешле күләмдә булмаган; чак кына; гадәти күләмгә якын да килмәгән. *Бер димим, ярты, хәтта чирек адым читкә атласак та, җәһәннәмгә очачакбыз.* Г.Әпсәләмов. *Әчәм, әмма минем берәүгә дә чирек начар сүз әйткәнем, исереп аунап ятканым юк.* М.Хуҗин. *Әткә-әнкә җитәкләгән очракта да, чирек адым атлый сабый нибарысы!..* Ф.Гыйззәтуллина

2) Чагылышы интенсив булмаган, тулы рәвештә чагылмаган. *Мин төсләр, ярым, чирек төсләргә табынам.* А.Хәсәнов

3) Берәр сыйфаты тиешле дәрәҗәдә булмаган, көчсез, авыру, дәрәҗәсез. *Ә син – чирле кеше, чирек кеше ---.* М.Шабаев

◊ **Чирек бәһа** *к.* **чирек бәя**. *Базар уртасында байлар гына күркә шикелле кәпрәеп йөриләр, чирек бәһага урак урыр өчен көнлекчеләр яллыйлар.* М.Галәү. **Чирек бәя** Бик арзан, очсыз бәя. *[Авылда] Рамазан бай кебек, ярлыларның, батракларның җирләрен чирек бәясенә сатып алып, шул җирне тамак ялына үзләреннән эшләтеп килүче берничә генә кеше булган.* М.Гали. *Үзен теләсә нинди җисемле сынландыруны куллануданн тартынып тормыйча әрләде: шыр тиле, дивана, ахмак, надан, кем инде сиңа тиктомалдан чирек бәясенә машина китереп тоттырсын!* Т.Галиуллин. **Чирек хак** *к.* **чирек бәя**. *Бу җеназага җыелган халык эчендә үзенең күп алыш-биреш эшләрен үтәү исәбе белән килгән, заманында казак даласында җон-ябаганы чирек хакка алып, әйберне биш мәртәбә кыйммәт сатып, үлчәүдә һәр ике тәкъдирдә алдашып баеп киткән якын шәһәрнең татар сәүдәгәре моңа каршы тагын арттырды ---.* Г.Ибраһимов

**ЧИРЕКЛӘП** *рәв.* 1) Бөтенне дүрт өлешкә, чирекләргә бүлеп. *Чирекләп уку системасы моны исәпкә алмый.* Мәйдан

2) Күләмен чирек кадәр итеп; чирекләргә салып; чирек-чирек, чирегечиреге белән. *Чирекләп эчү*

3) Авырлыгын чирек кадәр алып. *Әйе, чак кына элегрәк такта чәйне дә чирекләп я әчмухалап кына ала алган вакытлар онытыла барып, һинд чәйләренә ук өметләнә башлаган идек берзаман ---.* Татарстан яшьләре

4) Озынлыгын чирек белән билгеләп, чирек кадәр итеп. *Чирекләп үлчәү*

**ЧИРЕКЛЕ** *с.* 1) Бер чирек (*3 мәгъ.*) сыешлы. *Әлеге качак, ит туралып беткәндә, урындык-өстәл янына башына чокыр кидертелгән чирекле шешәдә хәмер китереп куя.* М.Хуҗин. *Үзе коры печән эченнән бер чирекле пыяла шешә китереп чыгарды.* З.Зәйнуллин

2) Озынлыгы бер чирек (*4 мәгъ.*) булган. *Алты чирекле зур җон яулыклар була, карт, карчыклар өчен, диярсең.* Г.Исхакый

**ЧИРЕ́КФИНАЛ** *и. махс.* Ярышның ярымфиналдан алда уйнала һәм моңа кадәр җиңеп чыккан сигез команда яки уенчы катнаша торган өлеше. *Бүген хоккей буенча плэй-оффта чирекфинал уеннары башлана.* Ватаным Татарстан. *Зур спорт ярышларындагыча, бөтен шартын китереп оештырылган турнир өч өлештән – чирекфинал, ярымфинал һәм финалдан тора иде.* Алабуга нуры

**ЧИРЕ́К-ЧИРЕК** I *иярт.* Кайбер кошларның, чебиләрнең, чикерткәләрнең нечкә генә итеп чыркылдау тавышын белдерә. *Пип-пип, чирек-чирек! Кош теле белән әйткәндә: «Сабыр. Сабыр, ашыкма, безне дә көт, бергә чыгыйк!» – дигән сүзләре инде бу.* Ә.Баян. *Яңгыр туктауга кузгалды Черкие, кигәвене. Чикерткәләр чирек-чирек Берәр җыр көйләвеме?..* Н.Әхмәдиев

◊ **Чире́к-чирек килү** Чирек-чирек сыман тавыш чыгару, нечкә генә чыркылдау. *Асылган казанында итле шулпа пешә, уңдарак олы борынлы бер әрмән агае шашлык кыздыра, арырак ике чибәр туташ, өстәл хәстәрен күреп, купшы чыпчыклардай чирек-чирек киләләр.* Ф.Яхин

**ЧИРЕ́К-ЧИРЕК** II *с.* **1.** Берничә чирек күләмендәге; чирекләргә салынган. *Ике ихата арасында тәбәнәк читән генә, ә күрше өйнең тәрәзәләре киңенчә ачык, шунлыктан барысы да – сәкедәге чирек-чирек кымызлары да, табак тулы итләре дә һәм кунаклар үзләре дә ап-ачык күренеп тора.* Ә.Еники

**2.** *рәв. мәгъ.* Чирегe белән, чирек итеп // Чирекләп, чирекләргә бүлеп

**ЧИРЕ́К-ЧОРЫК** *с. сөйл.* Бик аз булган, ярым-йорты. *Ләкин ярлы оешманың барлы-юклы гына акчасына чыгарыла торган «Әльислах»тан алган чирек-чорык гонорарлар гына Тукайның тормышын тәэмин итә алмыйлар.* Г.Камал

**ЧИРК** *иярт.* **1.** Берәр нәрсә кинәт чатнаганда, ватылганда, пластмасса сынганда барлыкка килгән тавышны белдерә

**2.** *хәб. функ.* Шуңа охшаш тавыш барлыкка китереп ватылуны, чатнауны

белдерә. *[Гәрәй:] Кереп эшли башладымы, [забой] чирк! [Садри:] И гөмберт*. Ш.Камал

**ЧИРКАНДЫРГЫЧ** *с. к.* **чирканыч**. *Таулар арасыннан безнең якның чиркандыргыч җиле исә*. Ә.Еники. *Беләкләрне авырттырып, чиркандыргыч салкын металл, корыч беләзек – наручник кысып алды*. М.Юныс. *– Мин синең кебек ямьсез вә чиркандыргыч затны дөнья йөзендә һичбер вакытта очратмадым! – дияр*. Ф.Яхин

**ЧИРКАНДЫРУ** *ф.* 1) *зат-сыз* Салкыннан тән өшеп китү, калтырап кую, җиңелчә чәнчешү. *Көндезге бөркүлекнең эзе дә калмаган – салкын төшкән, чиркандыра.* Т.Әйди

2) Җирәндерү, җирәнү хисе уяту. *Чөнки аның мәче күзләрен елтырелтыр китереп, мал карагандай сөзеп каравы, мышнаулары мине чиркандырды*. Г.Кутуй

**Чиркандыра башлау** Чиркандыру билгеләре барлыкка килү. *Аңа көзге суык чиркандыра башлаган карт сөяген җылытырга кирәк иде.* Ш.Маннапов

**Чиркандырып алу** Азга гына чиркандыру. *Булатны салкынча һава агымы чиркандырып алды.* Ә.Гаффар

**Чиркандырып җибәрү** Бераз чиркандыру. *Ә шулай да бик нык куркытып, чиркандырып җибәрде.* В.Нуруллин

**Чиркандырып кую** Кинәт чиркандыру. *Ишкәкләрдән чәчрәгән салкын су тамчылары Мәрхәмбикәне чиратып, чиркандырып куя.* М.Хәсәнов

**Чиркандырып тору** Күпмедер вакыт дәвамында чиркандыру; әле чиркандыру. *Һәм мөнә болар барысы да, ниндидер билгесезлек эченә чумган буш хыял булып, халыкның күңелен өшетеп һәм чиркандырып тора.* Ф.Яхин

**ЧИРКАНУ** *ф.* 1) Салкыннан яки берәр начар нәрсәне күрүдән, тоемлаудан тәндә өшү, калтырау, җиңелчә чәнчешү сизү. *Бер-ике адым алга атладым да, бизгәк тоткандагы кебек туңып, чирканып, дерелди башладым.* И.Салахов

2) Җирәнү. *Газинурның көләч йөзе караңгыланды, ул, чирканган сыман, Сәлимнең кулын этәрде, коры тавыш белән: – Яхшылап сөйлә! – диде*. Г.Әпсәләмов. *Нәсимә аны яратмый гына түгел, җирәнә һәм чиркана иде.* И.Хуҗин

**Чиркана башлау** Чиркану билгеләре күренү. *Кайвакыт бөтенесен тәфсилләп уйлаганнан соң, кырык яшьлек кеше белән яшәвемнән үзем дә чиркана башлыйм.* З.Хәким

**Чиркана төшү** Беркадәр чиркану. *Ул безгә, авылдан килгән ябык кына, юаш кына кыяфәтле егетләргә, үзенең чиркана төшүен яшермичә карап алды*. Р.Фәизов

**Чирканып китү** Көтмәгәндә чиркану. *Җамалиның тәннәре чирканып китте.* М.Гали. *Хәтеремә килгән саен әле дә чирканып китәм, әйтерсең лә мин бер оят эшнең шаһиты, хәтта катнашчысы булганмын.* М.Кәрим

**Чирканып кую** Аз гына яки бер тапкыр чиркану. *Әле хәзер дә чирканып куйды Фәләх: башы бары тик шул пальтоның башлыгы белән генә капланган.* В.Нуруллин. *Егет үз уйдырмаларыннан үзе үк чирканып куйды.* А.Хәлим

**Чирканып тору** Әле, хәзер чиркану. *Төнге җил әле болай да теңкәгә тиячәк, әнә хәзер үк тәне өшеп, суыктан чирканып тора кебек.* Л.Хәмидуллин

**ЧИРКАНЧЫК** *и.* 1) Салкыннан, берәр начар нәрсә күрүдән һ.б.ш. туңып куйган кебек булу, тән чемердәү күренеше. *– Имгәнүчеләр, һәлак... булучылар юкмы? – диде ул, тәненә салкын чирканчыклары бәреп чыкканны сизеп.* Г.Кашапов

2) Гадәтидән салкынрак суда коеныр, су керер алдыннан бер мәртәбә өстеңә су сибеп яки чумып карау, шуннан булган чиркану халәте. *Ә син чирканчык алмыйча ук бозлы суга ташланасың!* М.Хуҗин. *Ниһаять, һәммәсе чирканчык алды. Ә эчкәрәк тә кергәч, су май кебек тоелды.* А.Тимергалин

3) *күч.* Беренче сынау. *Разиянең фаҗигасы – буйсындыруга, саф күңелле яшь кыздан шымчы ясарга омтылышның ямьсез, чирканчык нәтиҗәсе.* Г.Гайнуллина

◊ **Чирканчык алу** Берәр яңа эшне беренче мәртәбә эшләп карау, шул эштә беренче сынау үтү. *Аны Россия шәһәрләренең берсенә җибәрделәр, ул шунда чирканчык алды, чыныкты ---*. А.Гыйләҗев. *Чиксез зур шатлыгын, затлы сәнгать дөньясында уңышлы чирканчык алуын кем белән уртаклашсын?* А.Хәсәнов

**ЧИРКАНЫЧ** *с.* 1) Чиркандыра (*1 мәгъ.*), тәнне чымырдата торган. *Көзгә тарткан җәйге иртә барыбер дә чирканыч суык икән.* Ә.Әминев. *Салкын, чирканыч саз суы эссе тәнемә ябышып, дерелдәтеп җибәрде.* Г.Әпсәләмов

2) Җирәндерә торган, җирәнү хисе уята торган. *Җахыйз гаять чирканыч йөзле иде.* К.Насыйри. *Баз капкачын ачып җибәрүгә, түбәннән күтәрелгән әллә нинди чирканыч ачы ис ни заманнан бирле юньле ризык күрмәгән ашказанын ертып үтте дә бөтен эчен умырып алды.* Г.Әдһәмова

3) Чиркануны белдергән. *[Закир (ялгыз, ишеккә чирканыч карау белән карап):] Аһ, бу йөзе каралардан ничек тиз генә котыласы?* Г.Камал

4) *күч. к.* **чирканчык** (*3 мәгъ.*). *Бу беренче чирканыч аларның рухын сындырырга тиеш түгел.* С.Поварисов

◊ **Чирканыч алу** *к.* **чирканчык алу**. *Булачак «Мәрҗәннәр» авторы шулай беренче чирканыч ала, язган әлеге хикәяләре, әлбәттә инде, «Шура»га үтмәс иде.* М.Мәһдиев

**ЧИРКАНЫЧЛЫК** *и.* Чирканыч (*2 мәгъ.*) булу сыйфаты, җирәнечлек. *Хатын шәмәхә һәм кызыл төстәге киемнәргә киенгән, алтын, асылташлар һәм энҗе белән бизәлеп матурланган, кулына үзенең фәхешлегенең чирканычлыгы һәм шакшылыгы тулы алтын касә тоткан иде.* Инҗил. *Ул хәшәрәтне үлгәч түгел, исән чагында ук хурлык баганасына кадакларга, аның чирканычлыгын бөтен кабахәтлеге белән ачып салырга кирәк.* Г.Тавлин

**ЧИРКӘС** *и. сөйл.* 1) Башлыча Карачай-Чиркәс республикасында, Краснодар, Ставрополье крайларында яшәүче халык һәм шуның бер вәкиле. *Чиркәсләр бар икән бит, шуларны мылтыклары белән каравылга ялламакчы бугай.* Г.Ибраһимов. *Ул арада кибетче чиркәс бер читтә басып торган Саҗидәне күрде дә ачуы сүрелгәндәй булды.* М.Галәү

2) *иск.* Төньяк Кавказда яшәгән халыкларның гомуми исеме һәм шуларның бер вәкиле. *Ә гаскәр үзе, нигездә, яулап алынган халыклардан, шул ук бөек фарсы тарихчысы әйткәнчә, чиркәс, мажар, кыпчак, хәтта русларның үзләреннән дә туплана.* Р.Фәхретдинов

**ЧИРКӘ́СЧӘ** *рәв.* **1.** 1) Чиркәс телендә. *Чиркәсчә сөйләшә*

2) Чиркәсләр кебек, шулар гадәтенчә. *[Сабах:] Ас-са! (Чиркәсчә биегән булып кылана).* Р.Зәйдулла

**2.** *с. мәгъ.* Чиркәс телендә булган. *Чиркәсчә текст*

**3.** *и. мәгъ.* Чиркәс теле. *Бу сүз чиркәсчәдә «кара урман» дигәнне аңлата*

**ЧИРКӘҮ** *и. рус* 1) Христиан дине руханиларының һәм шул динне тотучыларның ышанулары һәм йолалар системасы уртаклыгы нигезендә берләшкән дини оешмасы; шул оешма

тоткан дин. *Архиерей – православие чиркәвендә иң югары дәрәҗәле руханиларның (епископ, архиепископ, митрополит һәм патриархларның) гомуми исеме.* А.Тимергалин. *Никон елъязмасы XVII гасырның мәшһүр чиркәү эшлеклесе патриарх Никонныкы булган кучермәләрнең берсе буенча шулай аталып йөртелә.* Б.Хәмидуллин

2) Христианнарның гыйбадәт кылу бинасы. *Православиедә үлгәннәрне чиркәүдә литургия вакытында искә алуны да тәберсен итү диләр.* А.Тимергалин. *Аның урамнарын дисталәрчә чиркәүләр, костёллар, мәчетләр, синагогалар били.* А.Хәсәнов

◊ **Чиркәү кагу** 1) Христианнарны гыйбадәткә чакырып яки башка берәр рәсми максат белән чиркәүдә чаң кагу. *Аннары таң вакытында барлык чиркәүләр кага башлады.* Казан утлары; 2) *к.* **чаң сугу**. *Тукай үлде, диеп дан тотабыз, Тукай үлде, диеп орден тагабыз... Әйтерсең лә Тукай – тимер чүлмәк, Инде ватылды дип, чиркәү кагабыз.* Р.Ногмани

**ЧИРКӘҮЛӘШТЕРҮ** *и. дини* Тарихи чиркәүләрдә (православие, католиклык һәм Борынгы Көнчыгыш чиркәүләрендә) бала туганның 40 нчы көнендә инде моңа кадәр чукындырылган баланы һәм аның анасын чиркәү җәмгыятенә кертү, чиркәү әгъзасы итү йоласы; *русчасы:* **воцерковление**

**ЧИРКӘҮЛЕ** с. Билгеле сандагы яки билгеле сыйфаттагы чиркәве булган; гомумән чиркәве булган, чиркәү салынган, чиркәү урнашкан. *Безнең Луговое – өч чиркәүле авыл.* А.Хәсәнов. *Сугыш турында, авыл хәлләре, дөнья киләчәге турында сөйләшә-сөйләшә, инеш буйлап түбәнгә – ике чакрымдагы Благодатное дигән урыс авылына чаклы җиттеләр, чиркәүле тауга күтәрелделәр.* Ә.Гаффар

**ЧИРКӘҮ-МӘХӘЛЛӘ** *и.* Изафәле тезмәләрдә «чиркәү һәм мәхәллә руханилары карамагында булган, башлангыч (мәктәп тур.)» мәгънәсен белдерә. *1870 елдан 2015 елга кадәр әлеге мәктәп берничә тапкыр исем алыштырган: әле чиркәү-мәхәллә, әле эшче-крестьян яшьләре мәктәбе булган.* Кама ягы

**ЧИРКӘҮ-СЛАВЯН** *и.* Изафәле тезмәләрдә «хәзерге көндә православие чиркәвенең теле булган, элек (XI–XVI гасырларда) көнчыгыш һәм көньяк славяннарда әдәби тел урынына йөргән борынгы славянча» мәгънәсен белдерә. *Кирилл һәм Мефодий турындагы «Житияۍ»нең чиркәү-славян тәрҗемәсендә: «Херсонеста Кирилл урыстан урысча белем алды», – диелгән.* М.Хәбибуллин

**ЧИРКӘҮЧЕЛЕК** *и.* Чиркәү тәгълиматы; *русчасы:* **церковное учение**

**ЧИРКЕН** *с. иск. диал.* Начар, яман; җирәнгеч. *Үзен сөям, кызганам, дустым дип, кочагыма аласым килә, шулвакыт ук аны бөтен мәдрәсәгә чиркен кыяфәттә сурәтлим.* Г.Ибраһимов. *Һәммәсе бик күңелле генә, ләкин хатын ролен ирләр уйнаганга, бик чиркен бер хис калдыра.* Фәнни Татарстан

**ЧИРЛӘҮ** *ф. сөйл.* 1) Авыру, берәр чир белән интегү, сырхаулау. *Үзе бераздан ук чирләп, үлеп тә киткән, ди.* Г.Бәширов. *Чирләп ауганнан бирле һәрнәрсәгә шик белән карарга, берәүгә дә ышанмаска күнегеп баручы Нәҗипнең шикчеллеге өскә чыкты ---.* А.Гыйләҗев. *Муса агай, авырыйм, чирлим, дип зарланырга ярата.* И.Юзеев

2) *күч.* Берәр тискәре, начар сыйфатка ия булу. *Битарафлык белән чирлибез без...* Р.Харис. *Чирли татар, булмый терелтеп. Җыелганда бергә, аңлашабыз Ике ярым телне бер итеп.* И.Сабиров

3) *күч.* Берәр нәрсә белән бик мавыгу. *Футбол белән чирләү*

**Чирләп алу** Бераз, беркавым чирләү; җиңелчә чирләү. *Бала чакта һәркем кызамык белән авырган кебек, мәхәббәт белән дә чирләп аладыр инде.* А.Гыйләҗев. *Зыялылар шундый сәяси сабырлык белән чирләп алалар икән ---.* Р.Миңнуллин

**Чирләп бетү** Бик каты чирләү; барысы да чирләү. *Тозсыз аш ашап, балаларыбыз чирләп бетте!* Г.Бәширов. *Иртәнгә кадәр монда басып торып чирләп бетәсез бит.* Р.Зарипов

**Чирләп китү** Кинәт чирләү. *Көз башларында авылдан борчулы хәбәр килеп иреште: әнисе чирләп киткән.* Г.Әдһәмова. *Бала куркудан чирләп китсә, ялгыша башласа, зиһенен буташтырса, шушы йоланы башкаралар.* Г.Гыйльманов

**Чирләп кую** *к.* **чирләп китү**. *Юлда берәр пассажир акча биреп китсә, икенче көнне үк өйдә я бернәрсә ватыла, яисә кем булса да чирләп куя.* З.Мурсиев

**Чирләп тору** Әледән-әле чирләү, әле, хәзер чирләү. *Чирләп торам, хәлем әйбәт түгел...* З.Хәким. *Бозавыбыз чирләп тора.* Ф.Җамалетдинова

**Чирли башлау** Чирләргә тотыну. *Грипп-фәлән эләгеп, азрак чирли башласа, тозлап-борычлап, бер стакан акны салып ятып йоклый да иртән торуга авыруы юып алгандай була торган иде.* В.Нуруллин. *Мәдрәсәдә матур әдәбият китапларын яратып укый, бигрәк тә Г.Тукай, С.Рәмиев шигырьләрен якын күрә, үзе дә шигырь язу белән чирли башлый.* К.Гыйззәтов

**ЧИРЛӘШ** *с. диал. к.* **чирләшкә**. *Кызгануын күрсәтергә тырышмаса да, хатын, чирләш баланы җәлләп, аңа күбрәк игътибар, тәрбия бирде.* Авыл офыклары

**ЧИРЛӘШКӘ** *с. сөйл.* **1.** Сәламәтлеге начар булган, чирләүчән, чирле. *Каз шикелле озын муенлы, ябык, чирләшкә кыз матур буламыни?!* Г.Әпсәләмов. *Бүреләр бит беренче чиратта көтүдәге гарибрәк, аңгырарак, чирләшкәрәк затларны аяктан ега, бугазлый.* А.Хәсәнов

**2.** *и. мәгъ.* Сәламәтлеге начар булган, чирләүчән, чирле кеше. *Нишләтеп дәваларга андый чирләшкәне?* Г.Бәширов. *Мин, икенче катка менә алмаган чирләшкә, бүген тауларга күтәреләм.* Г.Әпсәләмов

**ЧИРЛӘШКӘЛӘНҮ** *ф. сөйл.* Чирләшкәгә әйләнү

**ЧИРЛЕ** *с. сөйл.* **1.** 1) Чире булган, авыру, хаста. *Арбаларның, иярле атларның, өйләр арасындагы халыкның саны арткан саен, бу бәйләүле малларга да мәрхүмнең фидиясе өчен дуслары, кардәшләре тарафыннан китерелгән буталар, кысыр биячәр, яшь тайлар, чирле башмаклар, рәнҗү куйлар һаман кушыла бара, кушыла бара...* Г.Ибраһимов. // Авыру кичергән. *Яңгура башта бу тойгыга да тән белән күңелнең чирле бер чагы, узгынчы бер кичереш дип кенә караган иде.* Г.Әпсәләмов

2) Авыруларга хас, авыру билгеләре чагылдырган. *Идел ярында җәй уздырып, чуен тәнле яшь-җилкенчәк арасыннан килгәнгә, аның чирле аклыгы, өстенә ябынган ак җәймә белән кушылып, аерата күзне кисте...* А.Гыйләҗев

3) *күч.* Начар, тискәре; проблемалы. *Кыскасы, бүгенге җәмгыятебезнең кайбер чирле нокталарын дөрес билгеләп, спектакль аларны үтемле төстә фаш итә ---.* А.Әхмәдуллин

**2.** *и. мәгъ.* Авыру кеше. *Бурычлы үлми, чирле үлә, ди татар, Тик шулай да, бурычлының эше хәтәр.* В.Ильясов

◊ **Чирлегә сабышу** *к.* **авыруга сабышу**. **Чирле чебеш** Авыру, бик зәгыйфь кеше. *Өф-өф итеп мич ба-*

*шында тотарга чирле чебешме ул, я?!* А.Гыйләҗев

**ЧИРЛЕЛЕК** *и.* Чирле, авыру булу күренеше. *Чирле түгел иде безнең кавем, Тик гадәткә керде чирлелек.* Б.Ибраһим

**ЧИРЛЕ́-ЧОРЛЫ** *с. сөйл.* **1.** Чире күп булган, чирләшкә булган. *Аннан, чирле-чорлы балалар туа, дип аптырыйлар.* Саба таңнары

**2.** *и. мәгъ.* Авыру, чирләшкә кеше. *Юк, ахирәткәем, чирле-чорлы белән язмышымны бәйләп, фәкыйрьлек баткагына батучы мин түгел.* Р.Мулланурова

**ЧИРМЕШ** *и. иск.* Мариларның элекке атамасы. *Сугышта 150 мең кешедән торган Мәскәү гаскәре (шуларның 61 меңе Мәскәү кенәзлегеннән, 54 меңе Касыйм ханлыгыннан, ә 35 меңе хыянәтчел татар, мишәр, типтәр, чирмеш, ар, башкорт яугирләре булган) катнаша.* А.Тимергалин. *Кайбер галимнәр фикеренчә, безнең эраның беренче меңьеллыгы ахырында ук борынгы марилар чирмеш исеме белән инде, нигездә, формалашкан халык буларак танылалар.* Б.Хәмидуллин

**ЧИРТЕШ** *и.* 1) Чиртү хәрәкәте. *Ә без синең белән, иң яхшысы, шашка уйныйк. Биш тапкыр маңгайга чиртештән.* Д.Вәлиев

2) Агачтан ясалган шакмакларны билгеле бер кагыйдәләр нигезендә чиртә-чиртә җыеп алудан гыйбарәт балалар уены. *Әнә ул сәкедә чиртеш уйнап утыра.* М.Шаһимәрдән. *Шуннан соң ул әлеге Сукыр Тычкан малае белән әйлән-бәйлән, бишташ, өй-өй, йөзек салыш, пәке кадаш, кузна, чиртеш уеннары уйнаган, биегән, җырлаган – тагын әллә нишләп беткән.* Ә.Гаффар

3) Чиртеп шуып, тәгәрәп киткән шакмакның баштагы һәм хәзерге торышы арасындагы ара. *Юк, төптән чиртеш буе өстәрәк.* К.Кәримов

4) *диал.* Калкавыч. *Кармак саплары, чиртешләр, тегесен-монысын сатып алдым, аларны үземчә көйләгән булдым.* Р.Фәизов

5) *күч.* Төрттереп, кинаяләп әйтү. *Кара-каршы чирәмгә тезелешеп (уртада баянист була), бер-берсен төрттереп «Чиртеш җырлары»н башкарганнар.* Милли-мәдәни мирасыбыз: Нижгар татарлары

◊ **Чиртеш хәтле** Бик кечкенә. *Өч батырга тиң Низам чиртеш хәтле малай алдында куркак куянга әверелә.* К.Кәримов

**ЧИРТЕШЛЕ** *и. к.* **чиртеш** (*2 мәгъ.*). *Менә чиртешле уйнап утырам.* М.Галәү. *Энем кайтып җитсә, шахмат, чиртешле уйныйсы бар, әбәкле, качышлы, тәкмәч атышлы, парланган тәрәзә пыялаларына бармак белән сызып рәсем төшерешле.* Д.Булатова

**ЧИРТКЕЛЕ** *и. диал. к.* **чиртеш** (*2 мәгъ.*). *Чирткеле уйнамыйбыз, уголовный җинаять тикшерәбез!..* А.Гыйләҗев

**ЧИРТКЕЧ** *и.* **1.** 1) *к.* **медиатор**

2) Калкавыч. --- *балык тотучылар өчен шушы вакыттан алып 15 июньгә кадәр бер чирткечле кармак яки яр кырыеннан ике чирткечтән дә артык булмаган су асты кармагы белән балык тоту уылдык чәчү урыннарыннан ягада рөхсәт ителә.* Туган як

3) Җәелгән камырны кисәкләргә кисү өчен түгәрәк кискеч. *Кайвакытта җәймә зуррак булып китсә, кырыйларын чирткеч белән кисеп алалар.* Халык ашлары

4) Бүрәнәгә туры сызык төшерү өчен җеп, шнур. *Чирткеч белән эз төшерү*

5) *к.* **чакма**. *Утлы мылтыкларның тәтесе (кулса, русча – спусковой крючок, Тубыл-Иртеш яклары сөйләшендә – сәмек), чакмасы яки чирткече (курок), филтәсе (чакма мамыгы), келәсе (йозагы, русча – затвор) һәм нишаны (прицел белән мушкасы) булган.* А.Тимергалин

**2.** *с. мәгъ.* Чиртә торган. *Кайсыдыр төбәкләрдә ул смычоклы (сызгычлы) коралны аңлата, кайберләрендә варган (чирткеч идиофон) мәгънәсендә кулланыла.* Г.Рәхим

**ЧИРТКЕ́Ч КОҢГЫЗ** *и. зоол.* Чирткеч коңгызлар семьялыгыннан ялтырап торган кара, коңгырт төстәге озынча гәүдәле коңгыз; *русчасы*: **челкунщик**. *Болар – чирткеч коңгыз (челкунщик) личинкалары.* Өмет

**ЧИРТКЕ́Ч КОҢГЫЗЛАР** *и. күпл. зоол.* Коңгызлар отрядыннан сикергәндә черт сыман тавыш чыгара торган коңгызлар семьялыгы

**ЧИРТЛЕК** *и. к.* **чиртеш** (*2 мәгъ.*). *Чиртлек уйный идек.* Ш.Галиев. *Кайбер очракларда чиртлек уены нәтиҗәсе маңгай шешү белән, ягъни алдан килешү буенча оттырганы чиртлек санынча маңгайга чиертү белән тәмамлана иде.* Казан утлары

**ЧИРТМЕШ** *и. к.* **чиртеш** (*2 мәгъ.*). *Әти чикләвек агачын кисеп ясап биргән таякчыклар белән чиртмеш уйныйбыз, иң оста уенчы – әниебез.* Татарстан яшьләре

**ЧИРТТЕРҮ** *ф. к.* 1) **чиртү** I. *Фаил бездәй малайларның Борынына чирттерә.* Р.Миңнуллин. *Рәшит белән Муллахмәт абыйлар өстәге тугайда балык тоталар, аларның егет чагы, ә без – 11–12 яшьлек Түбән оч командасы, Тегермән асты суында таш чирттереп уйныйбыз.* Р.Газиз

2) *сөйл.* Кыллы музыка коралында уйнау. *Океан-диңгезләр кичкән. Гитара чирттерәләр. Испанча да французча Җырларны сиптерәләр!* Ш.Галиев. *[Ул] --- башкорт җәйләүләренә чыгып, кымыз эчә һәм кубыз чирттертеп, курай уйнаттырып, нәзек кызларга сокланып, нечкә билләрне биетеп гомерен уздыра торган булган, ди.* Ф.Яхин

3) Музыка коралларында, сынау өчен, теләр-теләмәс яки уйный белмичә генә уйнау, баскалап кына карау. *Шагыйрьләр яңа шигырьләрен укый, композиторлар әле генә күңелләреннән кайнап чыккан көйләрен Дамирларның пианиноларында чирттерә.* Ф.Яруллин

4) *сөйл.* Кармак белән балык тоту. *Бераз гына түбәндә – Тугай җирдә, тирәндә – Балык чирттерә Вәли.* Н.Әхмәдиев. *Балык чирттерә торган урыныбыз бераз ипсезрәк.* А.Хәсәнов

5) *күч.* Эләктерү, кулга төшерү // Егет белән кыз сыйфатында аралашу тәкъдим итү, егет кыз артыннан йөрү. *Каргалының үзләренә артык нык ышанган кайбер актив егетләре дә Зөләйха артыннан бик чирттереп карыйлар.* Ә.Еники

6) *күч. сөйл.* Хатын я иргә хыянәт итеп, икенче ир яки хатын белән йөрү. *Аннан син аның хатынын чирттерәсең бугай, ә?* Г.Каюмов. *Шулай да берара халык телендә, Мостафинның Нәҗиясе раймагтагы кара мыеклы егет белән чирттерә икән, дигән хәбәр йөргән иде.* Ә.Еники. *Зөлфәтең Рәхилә артыннан нык кына чирттерә бит.* А.Гыйләҗев

7) *күч. гади с.* Урлау, чәлдерү. *Кассадан акча чирттерү*

8) *күч. сөйл.* Спиртлы эчемлек куллану, салу. *– Безнең Гаяз тагы печтек кенә чирттергән, – диде таза бәдәнле эшче.* А.Расих

9) *күч. сөйл.* Начар дип саналган эш эшләү. *Кыска итәктән чирттерү*

**Чирттерә башлау** Чирттерергә тотыну. *Ә курсларның комсомол секретаре чибәр-сылу Зөләйха артыннан бик каты чирттерә дә башлый.* Ә.Еники. *Алар үзара аңлашкан арада, Дәүләт-*

*гәрәй абзый скрипкасын көйләп җибәрде һәм, булдыра алган барлык осталыгын җигеп, янә «Әпипә»не чирттерә башлады.* Н.Фәттах

**Чирттереп алу** Тиз генә чирттерү. *Озын җепкә инә саплап, шуның белән ерактан гына чирттереп аласың.* Г.Бәширов. *Әле менә бүген дә ул радиодан, яраткан халкына мөрәҗәгать итеп, әхлак темасына кыска гына вәгазь чирттереп алды ---.* Д.Гыйсметдин

**Чирттереп җибәрү** Чирттерергә керешү. *Иң элек кайсы кылларын чирттереп җибәрәсең, җанкаем!* Ш.Камал. *Теге кеше ләшкәсе (таш) белән чирттереп җибәрә дә синекен чыгара, аннан теге кеше уйный.* Милли-мәдәни мирасыбыз: Мамадыш

**Чирттереп кую** Кисәк кенә чирттерү; бер тапкыр чирттерү. – *Әллә син мине эшкә шушы киемне киеп йөри, дип беләсеңме? – ул ике подтяжкасын да бер-бер артлы чирттереп куйды.* Ф.Садриев. *Лена юлына аркылы торган агач ботагын уң кулы белән читкә этәрде, ул тавыш-тынсыз гына чирттереп куйды.* М.Кәбиров

**ЧИРТҮ** I *ф.* 1) Урта яки имән бармакны баш бармак ярдәмендә бөкләп, аннан турайтып җибәреп кемгә яки нәрсәгә дә булса бәрү. *Нәсимәнең борынына нык кына берне чирттем, теләсә кая сузмасын.* А.Гыйләҗев. *Ногман аның башына чиртә.* Г.Каюмов

2) Гадәттә сигнал бирү өчен, ишетелер-ишетелмәс итеп кенә бармак очы белән бәрү. *Тик менә икене сукканда гына тәрәзә чиртteләр.* Г.Ибраһимов. *Уйларын бүлеп, кемдер тәрәзәгә чиртте, Һашимов куркып китте.* А.Алиш

3) Музыка коралының кылларына бармак очы яки медиатор ярдәмендә бәрү; кыллы музыка коралында уйнау. *Кыз чагында буш вакытында мандолина чиртә иде ---.* А.Гыйләҗев. *Мандолина, думбра кылларына да бик оста чиртә, кулы агач эшенә дә ябыша.* В.Нуриев

4) Балык кармакка кабу. *Балык та әйбәт капкан бәхетле көн иде: шәпшәп алабугалар шундый чиртте, алып кына өлгер!* А.Гыйләҗев. *Ник бер кармак чиртсен, ник бер калкавыч дерт итеп алсын.* А.Хәсәнов

5) Компьютер тычканының төймәсенә бармак белән басып алу. *Минем сайтка чиртсен әби, Кабызсын да компьютер!* И.Диндаров

6) *күч.* Кулга төшерү, эләктерү. *Эш шунда: Оксана апагызны Гаптелмөлек абыегыз тәки чиртеп китте бит!* Ф.Хөсни. *[Биктимер:] Бик асыл кошны чирттең!* И.Юзеев

7) *күч.* Кулга керү, эләгү. *Әйтте Әгъләм, шатланып: «Байлык чиртте!»* И.Юзеев

8) *күч.* Урлау, чәлдерү, шудыру. *Мөгаен, «Волга» машинасын чирткәннәрдер – Мәчтүрәйләр бакчасыннан чирткән алма дип белдең әллә?* А.Гыйләҗев. *Нотыклар сөйләп кич-иртә, Дәүләт акчасын чиртә шул. Чиртмәс тә иде кич-иртә, Тамак тәмугка кертә.* Г.Афзал

9) *күч.* Спиртлы эчемлек эчү. *Әллә егет бераз чирткән инде?..*

10) *күч.* Чыгымнар тотмыйча гына чит кешедән сорап алу. *Тукта, минәйтәм, куып тотып, берәр тәмәкесен чиртим әле, бер уңайдан кем икәнен дә белермен, дидем.* И.Хәйруллин

◊ **Чиртсәң егылырга тору** Бик хәлсез, көчсез булу. *Малахов кебек булсын иде, ә мондый чиртсәң егылырга торган кешедән нинди юньле разведчик чыксын соң, дип уйлады сыман ул.* А.Әхмәт. **Чиртсәң кан бәрергә тору** *к.* **чиртсәң кан (чәчрәп) чыгарлык**. *Әмма мин аңа Хисмәтулла агай биреп калдырган боерык кәгазен күрсәткәч, чиртсәң кан бәрергә торган каракучкыл кызыл йөзе кәфен шикелле агарып китте.* В.Нуруллин. **Чиртсәң кан тибәрлек** *к.* **чиртсәң кан (чәчрәп) чыгарлык**. *Күксә – түгәрәк йөзле, чиртсәң кан тибәрлек ир, ә бу – корып кипкән, борыны гына торып калган карачкы.* Л.Зөлкарнәй. **Чиртсәң кан чыгарга тору** *к.* **чиртсәң кан (чәчрәп) чыгарлык**. *Кияүне әнинең олы энесе, чиртсәң битеннән кан чыгарга торган таза гәүдәле ир урталары кеше – Сафа абый алып киләсе булды.* Г.Бәширов. *Хәдичә апа җиде йөз унтугыз хезмәт көне эшләгән, ә чиртсәң битләреннән кан чыгарга торган тап-таза дүрт ирнең, дүртесенекен бергә кушсаң да, Хәдичә апаныкы хәтле хезмәт көне юк!* В.Нуруллин. **Чиртсәң кан (чәчрәп) чыгарлык** Тулышып торган кызыл йөз; шундый йөзле, таза кеше. *Чиртсәң каны чыгарлык таза ир.* Г.Әпсәләмов. *Ишек пыялалары аша аларның чиртсәң кан чәчрәп чыгарлык тук чырайлары, кыйбатлы бүрекләре һәм текә күтәрелгән хәтәр танаулары гына күренеп кала.* А.Гыйләҗев

**Чиртә башлау** Чиртергә тотыну. *Җиңгән кеше сайлап алынган гаилә членнарының гаеп-кыек якларын атыйатый, җыелганнарны көлдереп чиртә башлый!* А.Гыйләҗев

**Чиртә килү** Әлегә кадәр чиртү. *Үскән саен дөнья серен ачты, Чиртә килде бөтен кылларны.* И.Киньябулатов

**Чиртә тору** Һаман чиртү. *Чирттең безнең борынга, энекәш!.. Шулай чиртә тор!..* Ф.Яруллин

**Чиртеп алу** Бер тапкыр яки җиңелчә генә чиртү; бераз чиртү. *Габбас тамак кырып куйды да Рәмиснең колагына чиртеп алды.* З.Мәхмүди. *Солдат гитарасын җайлап тотты да, кылларын үзәк өздерерлек итеп чиртеп алганнан соң, карлыккан тавыш белән җыр башлады.* Г.Гыйльманов

**Чиртеп җибәрү** Җиңелчә генә чиртеп кую; чиртә башлау. *Әйдә, Рифкать энем, чиртеп җибәр әле шул нечкә муенлы нәрсәңне!* Р.Вәлиев. *Икенчесе тәмәке төпчеген чиртеп җибәрде дә кулларын җәйде ---.* Р.Кәрами

**Чиртеп кую** Кинәт чиртү; бер тапкыр чиртү. *Берәр тустыган көмешкәне чиртеп куйгач, телләр чишелде.* Г.Гомәр. *Балык чиртеп куйдымы, әллә эче пошканнан, кармагын тартып чыгарды ул судан.* Р.Мөхәммәдиев

**Чиртеп тору** Даими, туктаусыз чиртү; әле чиртү. *Гомер буе чиртеп торса да балык, Нәфсе туймас, куллары армас кебек...* М.Мирза. *Ешрак чиртеп торса, ике кармакны төшерәсең.* Өмет

**Чиртеп чыгу** Баштан ахырга кадәр, һәммәсенә чиртү. *Олавызның бу эше өчен, барысы да аның маңгаена чиртеп чыга.* Ф.Яруллин

**ЧИРТҮ** II *ф.* Чикләвек, көнбагышны чистартып төшен ашау; яру. *Шуңа күрә Зифа иртә-кичен берәр җамаяк көнбагыш өеме чиртеп утырырга мәҗбүр.* В.Имамов. *Кайсы йон эрли, кайсы бәйләм бәйли, кайсыларыдыр симәнке чиртеп гайбәт саталар.* Д.Салихов // Эчендә төше булган кайбер вак җимешләрне шул төшен чистартып ашау. *Кыш буена көнбагыш урынына миләш чиртеп йөргән этигә кадәр гаҗәпләнде.* Р.Рахман. *Бер Риман абый рәхәтләнә: симәнке урынына чия чиртеп кайта.* Сәяхәтнамә

**Чиртә башлау** Чиртергә тотыну. *Бераздан соң ул тәмам канәгатьлек тапкан һәм җәһәт-җәһәт көнбагыш чиртә башлаган иде.* Ф.Яхин

**ЧИ́РТ-ЧИРТ** *ияр.* Чикерткә черелдәгән тавышны белдерә

**ЧИ́РТ-ЧИРТ ИТҮ** *ф.* Чирт-чирт сыман тавыш чыгару. *Мич ярыгында*

*чирт-чирт итеп кычкырган чикерткә тавышы гына караңгы төн тынлыгын боза иде.* К.Тинчурин

**ЧИРҮ** *и.* 1) *иск.* Гаскәр. *Солдатны да без бир, патшаның бөтен чирүен дә без туйдыр, атың белән әллә кайларга тикле олауларга да йөр.* Г.Бәширов. *Биш йөз кешелек кораллы чирү, хәбәр көтеп, Каратун тавы артында гына тора.* В.Имамов

2) *диал.* Көтү, өер (кайбер хайваннар, эт, бүре тур.). *Хутор аркылы Киев юнәлешендә аларның эт чирүе кебек яңа гаскәрләре уза.* А.Тимергалин

3) *күч.* Бик зур көч, ябырылып килгән дошман. *Соры шинельле Россия бөтен дөньяны фашизм чирүеннән йолып алды.* Г.Ахунов

4) *күч.* Кешеләр төркеме

**ЧИ́Р-ЧОР** *җый. и.* Төрле чирләр, авырулар. *Язгы ташкында бөтен чирчор, чүп-чар купкан кебек, сугыш заманында юлдан читтә яткан таш та кыймылдый, ди иде синең бабаң!..* А.Гыйләҗев

**ЧИРШЫК** *и. рус диал. к.* **чикерткә** (*2 мәгъ.*)

**ЧИСЕЛ** *с. сир.* Бераз чи, пешеп җитмәгән. *[Кузьманың] икмәкне чисел итеп, бәрәңгене изрәтеп пешергән хатыннарга да ихтирамы чамалы.* Ш.Камал

**ЧИ́СЛЕННИК** *и. рус к.* **числолык**. *Көне үткәч, численник битен дә ертып атасың.* Ф.Садриев

**ЧИСЛО** *и. рус* 1) Айның тәртип буенча билгеле бер көне. *Мартның ахыргы числолары, көннәр озая, дөньяга яз исе керә башлаган чак иде.* В.Нуруллин. *Бүгенге числоны, айны куярга онытмагыз.* Д.Салихов

2) *иск.* Календарь ае. *Числоның беренче көне иде.* А.Алиш. *Октябрь числосы кереп, дөньяның матурлыгы бетә башлады.* Г.Ибраһимов. *Май числосында ул тәмле-татлы язгы сөт кеби була.* Г.Исхакый

3) *сөйл. к.* **числолык**. *[Таймас (числоның битен ертып):] Уза көннәр.* А.Гыйләҗев

**ЧИСЛОЛЫК** *и. сөйл.* Битләре, гадәттә, ертып алына торган кечкенә китапчык формасында эшләнгән календарь. *Ничәмә календарь туздырдык, ничә числолыкның канатын йолкып ташладык.* Ш.Галиев. *[Ул] 20 елдан артык татар числолыгын да төзүче булды.* Ватаным Татарстан

**ЧИСТА** *с. рус* **1.** 1) Керләнмәгән, каралмаган, катмаган, пычранмаган, ару

2) Кере китәрелгән, юылган. *Ну, егетләр, хәлләр ничек, барыгыз да тереисәнме, берегезгә дә чиста күлмәкыштан кирәкмиме?* Ә.Еники. *Чиста кулъяулыкка гына төреп йөртердәй кеше ул минем кияү, бик беләсегез килсә.* Ф.Баттал

3) Пөхтә итеп җыештырылган, чистартылган. *Зур, якты, чиста бараклар.* А.Хәсәнов. *--- каралты-куралары һәрчак төзек, буяулы, җыйналган, чиста.* А.Хәйретдинова

4) Тәнендә, тиресендә кер булмаган, кердән арындырылган. *Юынып чыккач, чиста тән белән утырып намаз укыды.* Ф.Бәйрәмова. *Нинди генә причёска ясарга алынсаң да, исеңдә тот: чәчләр һәрвакыт чиста һәм каралган булырга тиеш.* Матур буласың килсә...

5) Өстендә саз, пычрак, кар кебек комачау тудырган нәрсәләр булмаган (юл, урын һ.б.ш. тур.). *Чиста урамнардан да йөрер көннәр булыр икән.* А.Гадел. *Бу уйларыннан күңеле булып, малаена урын юкка әллә ни исе китмичә, ул үзенең салмак адымнары белән чиста тротуардан атлый бирде.* Р.Кәрами

6) Пычрактан, калдыклардан, чүпчардан чистартылган; юылган. *Менә киң чиста идән.* М.Мәһдиев. *Чиста савытларны күреп, Әни... сөенсен әле!* Р.Миңнуллин

7) Пычрак булмаган, болганмаган, ару. *--- суы зөбәрҗәттәй яшькелт, бик чиста; күләгә урыннарда караңгыланып китә, бик коя шлы җирләрдә җемҗем уйнакларга тотына, ә шулай да, үз дәрәҗәсен белгәндәй, ашыкмыйча, уйчан-тыныч кына агып ята.* Ә.Еники. *Тырыша торгач, гөрләп, чиста су килә башлады.* А.Тимергалин

8) Чисталыкны ярата торган; чисталыкны саклый торган; чиста йөри торган. *Ничектер бигрәк пөхтә, чиста, көяз кеше икән.* Ә.Еники. *Ә үзе – табигате белән бик чиста бала.* Ф.Яруллин. *Шундый уңган, чиста хатын бит син, фатирыгызда бөтен нәрсә ялт итеп тора.* Т.Миңнуллин

9) Өслегенә, эченә бернәрсә дә язылмаган; язу, сызу, рәсем ясау һ.б.ш. өчен файдаланылмаган. *Паспортым чиста, моңарчы өйләнмәгән.* Ф.Яруллин. *Шуннан, көндез үк өенә хат язарга ниятләвен исенә төшереп, тумбочкасыннан шытырдавыклы пакетка салган иске хатларын, чиста кәгазьләрен алды да башта көнкүреш бүлмәсенә керде.* С.Шәрипов

10) Өстеннән әйберләре алып куелган, буш. *Өстәлнең бушаган әнә шул чиста өлешенә капитан Федотов ике терсәге белән таянды да, учын-учка кулларын тоташтырып, чал йөгергән зур башын шул терәккә салды ---.* М.Вәли-Барҗылы

11) Өсте шома, сырлар, таплар, бетчәләр белән ямьсезләнмәгән. *Аның муеныбите ап-ак шома, киң маңгае да ак мәрмәрдәй бик чиста, кыска гына калдырып китәргән коңгырт-аксыл чәчләре ефәктәй йомшак...* Ә.Еники. *Берсен – аркасына, икенчесен күкрәгенә төшереп салган озын толымнары, буяу әсәре күрмәгән түгәрәк чиста йөзе аны баласытып күрсәтә кебек.* А.Әхмәтгалиева

12) Тәнендә күгәрү, сыдырылу урыннары булмаган. *Малайның бер җирендә бернинди бәрелү юк, тәне чиста, тап-таза булуын әйтте.* Э.Фатыйхова

13) Болытсыз, аяз. *Бакалар кычкыра, этләр өреп куя, чиста күк йөзендә йолдызлар җемелди.* Ә.Әйлисли. *Биектә зәп-зәңгәр чиста күк.* Г.Ибушев

14) Саф, бөркү булмаган. *Шундый тәмле, чиста һава, сулап туймалы түгел.* Р.Габделхакова

15) Чүбе булмаган, чүпсез (ашлык һ.б.ш. тур.). *Чөнки аларның орлыгы, чиста булса да, безнең капчыкларга тутырылып кайта.* Т.Гыйззәт

16) Башка төргә караган нәрсәләр кермәгән. *Юк, бугазы, башы, аягы, тоягы кирәкми. Чиста итләтә генә, ямегез.* А.Хәмзин

17) Составында катнашмалар, кушылмалар булмаган; саф үзе генә булган. *– Орден чиста платинадан, рәсемнәре алтыннан, – дип, бүләкне тартмасыннан алып, безгә күрсәтте.* Р.Сәгъди. *Шәүкәт белән Толикның капчыкларында аерым очраклар өчен күз карасы кебек саклаган берәр ярты литр чиста спирт.* А.Хәсәнов // Катнашмалардан арындырылган, чистартылган. *Сыер бозаулаганнан соң берәр атна үтеп, угызы аерылып беткән, чиста, күбекләнеп, пары чыгып торган сөтне савып алып кергәннән соң башланган техник процесс турында сөйләмәкче булам.* А.Гыйльми

18) Физик көч таләп итми торган, авыр, пычрак булмаган; *киресе:* **кара**. *Барыгызга да чиста эш кирәк.* Р.Габделхакова

19) Сәламәтлеккә зыян китерердәй кушылмалары булмаган, шундый матдәләр бүлеп чыгармый торган.

*Җирдә бит күбрәк акча эшләп була, әле өстәвенә чиста һава да сулыйсың, чиста ризык белән тукланасың.* Таң. *Экологик чиста материаллар кулланып эшләнгән 100 квадрат метрлы өйне 1–1,5 айда төзеп бирәләр.* Кызыл таң

20) Башка милләт яки нәсел каны катнашмаган. *Кем, үз-үзенә ышанып, безне чиста төрекләр, әрмәннәр яки татарлар дип әйтә ала?* А.Нәҗми. *Чөнки нинди милләтне генә алма, анда фәлән милләт кешесе дип әйтерлек чиста канлы кешеләр юк дәрәҗәсендә.* Т.Нәбиуллин

21) Башка төрләр, төрчәләр катнашмаган. *Шулай булса, югары элиталы каракүл сарыклары һәм тире белән дан алган кебек үк, дөнья базарына чиста нәселле чаптарлар белән дә чыгып булыр иде.* Р.Мирхәйдәров. *Чиста гарәп токымлы дүрт яшьлек бу ат, ике чакрым дүрт йөз метр арада чабып, беренче урынны яулаган!* Кайбыч таңнары

22) Башка төсләр белән катнашмаган, үзгә төсмерләр алмаган. *Һәм бу чиста кара төс урманга сихрилек өсти.* М.Хуҗин. *Бу кадәр чиста зәңгәрлекне каян ала икән ул?* А.Хәлим

23) Кагыйдәләргә, нормаларга туры килгән, әдәби булган. *Хәзер казанча чиста «з» белән генә сиптерәләр.* А.Хәлим. *«Ничек кенә сөйләрмен инде», – дип борчылып чыккан иде дә, шулкадәр чиста татар телендә сөйләп китте, зал тын калды.* Р.Миңнуллин

24) Чын, тулы, тиешле таләпләргә җавап биргән; ачыктан-ачык күренеп торган. *Алар арасында чыганак (арадаш) телдәге исемнәрдән алда күрсәтелгән формантларны кыскартмый гына, кушымча өстәп фигыль ясау очраклары, ягъни чиста калька итеп кенә карап булмаган мисаллар да бар ---.* Р.Мөхиярова

25) Башка жанрлар, төрләр белән катнашмаган. *Чиста лирик булып туган Роберт Әхмәтҗаннарыбыз, Рәшит Әхмәтҗаннарыбыз да безгә «күптән таныш» эпикадан котыла алмады һәм алмый да.* А.Хәлим

26) Бик ачык яңгыраган, ямьсез тоннар, карлыгу һ.б.ш. булмаган. *Акчарлаклар тавышы, кинәт шунда иртәнге Идел өстендә Әлфинурның искиткеч чиста тавышы ишетелә.* Аманулла. *Югыйсә тиз генә арада шундый матур, чиста тавыш белән җавап бирә алыр идемени?* М.Вәли-Барҗылы

27) Барлык чыгымнарны да чигергәннән соң калган, кулга керә торган (акча, табыш тур.). *Кабатлап әйтәм, бу --- бандитларның чиста кереме генә.* И.Шиһапов. *Йөз дә егерме тугыз миллион алты йөз мең чиста табыш!* Д.Салихов. *Шуның аермасы табыш була, чиста акча кереме.* Акчарлак

28) *күч.* Эчкерсез; начар уй-ният булмаган, саф, риясыз. *Серле дәрвиш кебек йөри кеше, башы горур, чиста күңеле.* К.Сибгатуллин. *Аның кебек чиста йөрәкле, ачык күңелле кешене башка белмим.* Безнең гәҗит // Эчкерсезлекне, сафлыкны белдергән. *Егетнең күзләре шундый чиста, түзмәдем, бар, мин әйтәм, бездә аның Фәридәсе дә, Галиясе дә, Наиләсе дә бар, дим.* А.Гыйләҗев

29) *күч.* Начар булмаган, гаепле саналмаган; алдаусыз, намуслы. *Каян килгән чиста зат!* Г.Сабитов. *Миңа ул вакытта бүләге дә кирәкми, бары тик матур чиста көрәш күрсәтәсе генә килә иде.* Д.Сабиров // Законга каршы булмаган, коррупциядән, урлашудан азат. --- *Ли Куан Ю хакимияткә килгәч, үзгәрешләрне халыкка хезмәт итә торган сәяси система булдырудан, ришвәтчелекне бетерүдән, салым системасын үзгәртүдән башлады, үтәкүренмәле, чиста базар икътисады булдырды, закон каршында барлык кешеләрне дә тигезләүгә иреште.* И.Шәйхетдинов

30) *күч.* Гыйффәтле. *Бер җегет белән дә җөрмәде, чиста кыз.* З.Мәхмүди

31) *күч.* Уйларга сәләтле, аек фикерле алган. *Чөнки аның тәне исерек хәлдә булса да, зиһене ап-аек, чиста һәм сизгер иде.* Г.Рәхим. *Дәүләт чиста булсын! Чиста акыл булсын, чиста кул!* Р.Фәйзуллин

32) *күч.* Каршылыклар, киртәләр булмаган, җиңел. *Күтәрелү өчен, үзе дә гел чиста юлдан бармады бит.* Ф.Имамов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Пөхтә, җыйнак итеп. *Югыйсә, әлбәттә, минем кеби, романнар укыган, чиста киенгән, ислемайлар сөрткән, кершән ягынган, Әндәлүс гарәпләренең мәдәниятен белгән бер егет берлә ник сөешмәскә?* Г.Исхакый. *Кәрәзнең күзәнәкләрен төзәтергә, яшь балаларны тәрбияләп күзәтергә, күзәнәктә төренеп яткан бал кортларын җылытырга, өй эчен чиста тотарга...* А.Алиш

2) Пычранмыйча, керләнмичә; пычратмыйча, керләндермичә. *Сылу янында утырырга хаклы булу өчен, мин еш кырынырга, чиста йөрергә өйрәндем.* Г.Кутуй

3) Бөртекләп, берсен дә калдырмыйча. *Кул белән уручылар да, маңгай тирен агызгычыбыз да (лобогрейканы бездә шулай дип йөриләр) әйбәт, чиста уралар иде.* В.Нуруллин // Чүбен калдырмыйча, башка төр нәрсәләр белән катнаштырмыйча. *Җиләкне чиста җыю*

4) Тиешенчә, төгәл итеп, барлык шартларына туры китереп, кагыйдәләрне бозмыйча. *Дөрестән дә, көймә күргән кеше икән: ишкәкләрне бер дә көчәнмичә, җай һәм чиста сала – ник бер тамчы су чәчрәсен!* А.Тимергалин

5) Ахырынача җиренә җиткереп, камил итеп. *Кем әйтмешли, ул эшен чиста башкармаган.* А.Тимергалин

6) Әдәби нормаларга туры китереп, дөрес итеп; акцентсыз. *Сез чиста сөйләшкәнгә сокланып әйтүем.* Ш.Галиев. *– Комендант кайда? – дип сорый өлкән офицерлары, русча яхшы ук чиста итеп.* А.Тимергалин. *Үзбәкстанда туып үсүләренә дә карамастан, татар телендә бик чиста аралашалар.* Туган як

7) Тиешенчә, югары дәрәҗәдә; хатасыз итеп. *Әмма кушылган заданиеләрне төгәл һәм чиста башкарып чыга совет солдатлары.* Әлмәт таңнары. *Борынгы башкорт көйләрен чиста, матур итеп башкарды.* Кызыл таң

◊ **Чиста биттән** Элеккеләрне онытып, өр-яңадан, яңабаштан. *Тормышымны тәүге кардай ап-ак, чиста биттән башлар өчен, үз-үземнән качып, бик ерак, бик озын юлга чыктым мин.* Р.Габделхакова. *Бер кеше белән гаилә тормышының караламасын язып, аннан башка белән чиста биттән яшәп карап булмый бит инде.* Саба таңнары. **Чиста куллы** Урлашмый торган. --- *намусларын стаканга салмый торган, чиста куллы, чиста уйлы ирләр генә безнең сүзне, дөрес сүзне әйтә белә!* К.Сибгатуллин. *Безгә милләт өчен җан атып йөри торган чиста куллы, акыллы, исемле шәхесләр кирәк.* К.Кәримов. **Чиста суга чыгару** Ялган, җинаять һ.б.ш. гамәл эшләүчене фаш итү, гаепне күрсәтү, дөреслекне ачып салу. *Мин сезне чиста суга чыгарам әле!* Ф.Бәйрәмова

**ЧИСТАЙ** *и. рус* Татарстандагы Чистое поле авылыннан үсеп киткән шәһәр

◊ **Чистай малае** Сату аракысы, шешәле аракы; аракылы шешә. *Кайтканда, ике-өч чистай малаен сумкаңа тыгарга онытма.* Н.Гыйматдинова. *Безнең җитмәде, синең алып куйган чистай малаең юкмы?* Р.Зәйдулла

**ЧИСТАЛЫК** *и.* 1) Чиста булу; арулык; пөхтәлек. *Ата-бабадан калган гадәт буенча, келәттә өйдәге кебек үк*

*чисталык һәм ирләрчә тәртип хөкем сөрә.* А.Тимергалин. *Булмәнең идәне чиста иттереп юылган, бөтен җирдә чисталык, тәртип.* А.Гыймадиев

2) Сафлык, эчкерсезлек, риясызлык; гөнаһсызлык. *Яшьлек сафлыкны, чисталыкны ярата, чөнки үзенең күңеленә кер кунмаган.* Г.Әпсәләмов. *Хатынкызның итәге тишек булса, аның чисталыгын аяктагы калып саклыймыни?!* В.Имамов

**ЧИСТАРТКЫЧ** *и. махс.* **1.** 1) Су, орлык һ.б. нәрсәләрне төрле катнашмалардан, чүптән арындыру өчен махсус җайланмаларның гомуми атамасы. *Сырлап-боргалап, көннең-көн буена кәгазьләргә кул куйдылар, тамга ясадылар, чут төймәсе тарттылар, һәр склад ишеген, һәр чистарткычның, һәр бушаткычның ничек эшләвен күзәтеп торды ирләр.* Р.Мөхәммәдиев. *Йөз төрле чистарткыч аркылы үткәрсәң дә, Идел суы – эчә торган су түгел инде.* К.Кәримов

2) Берәр өслекне юып төшерү, нинди дә булса катламнан арындыру, сөртеп зарарсызландыру өчен махсус матдәләрнең гомуми атамасы. *– Менә шушы чистарткыч кебек бөтен проблемаларны да берьюлы алып ташлап булса иде, – диде ул бераздан.* М.Әмирханов

**2.** *с. мәгъ.* Чистарта торган, чистарту өчен хезмәт итә торган. *Кырда юлларны буран күмгән – чистарткыч машина әкрен генә юл ярып бара.* Ш.Галиев. *Тугызынчы бишьеллыкта гына да 546 чистарткыч объектлар төзү күздә тотылган иде.* М.Зарипов. *Чебен дүрт аягын терәп, урта аяклары белән канатларын аслап-өсләп чистарта да, ике аягының очындагы чистарткыч төкләрен кушырып, тузанын кага.* Р.Батулла

**ЧИСТАРТУ** I *ф.* 1) Берәр нәрсәне тузан, пычрак һ.б.ш.дан арындыру, чиста хәлгә китерү, чисталау. *Арзу җиргә төшкән дә озын куньнчлы, биек үкчәле ботинкаларыннан йомычка белән пычрак чистартып маташа.* А.Гыйләҗев. *Җир астыннан тапкан нәрсәләрне археологлар шундый йомшак пумала белән чистарталар икән.* А.Тимергалин. *Тыкрыкта казлар канат чистарта иде.* Н.Гыйматдинова // Берәр нәрсәнең өслеген тузанын, пычрагын, тутыгын һ.б.ш. сөртеп алып ялтырату. *Чистартып азапланганда, мин сәгать тартмасының эчке ягында карандаш белән тырналган язуга игътибар иттем.* А.Тимергалин. *Аннары, ком белән ышкып, күгәреген чистарттым.* Р.Вәлиев // Ату коралын тузан, тутык, дары кисәкчекләреннән һ.б.ш.дан арындыру, чиста хәлгә китерү. *Габдерәшит бабай мылтыгын чистартты һәм, бик сакланып кына, эре кургашын ядрә белән корды.* Гали Рәхим. *Мылтык көпшәсен шомпол («Аккалы кыз Туйбикә» дастанында – мылтык сөмбәсе, төректә – түфәк чыбыгы) белән чистартканнар ---.* А.Тимергалин

2) Тәнне кердән арулау, юынусөртенү. *Тәнне юып чистартып була. Ә менә җанны... Җаның пычранмасын, Рәмилә!..* Г.Гыйльманов

3) Яраны, кайбер әгъзаларны үлек, эрен һ.б.ш. нәрсәләрдән арындыру; чиста итү. *Аяктагы җәрәхәтне чистартып, гипска да салып карадылар.* З.Зәйнуллин. *Доктор Апушның күзен даруга манчылган мамык белән каткат чистартты.* Р.Батулла

4) Берәр урынны яки берәр нәрсәнең өстен, эчен чүп-чардан, чүп үләннән, кардан һ.б.ш. нәрсәләрдән арындыру; тазарту. *Йорт урыннарын, ишегалларын чүп-чардан арындырып, баз эчләрен чистартканнар.* А.Гыйләҗев. *Атың булгач, аны ашатырга-эчерергә, астын чистартып торырга да кирәк шул.* А.Хәсәнов. *Фаягөл, биләйләрен кулына тотып, «и сабыем, и нарасыем» дип кабатлый-кабатлый, карны чистартырга тотынды.* А.Әхмәтгалиева

5) Ашлыкның, җиләкнең чүбен аерып алу. *Чәчүлек орлыкларыбыз да әзер: чистартып, амбарга салып куелган.* В.Нуруллин. *Җиләк җыюын җыйдык та, өйгә кайтач, чистартасы да бар бит әле аны!* А.Галиева

6) Ашарга яраклы нинди дә булса нәрсәне, эчен-тышын эшкәртеп, чиста хәлгә китерү. *Балыкны чистартып, куырып аласы бар.* А.Гыйләҗев. *Аннан иң симез казны сайлап алды да эчен чистартты.* Г.Мөхәммәтшин

7) Кайбер яшелчә, җиләк-җимешне кабыгыннан арындыру, арчу. *Ә син бәрәңге әрче. Суган чистарт.* А.Гыйләҗев. *Крыжовникны юалар, әфлисунны чистартып телемнәргә бүләләр дә барысын бергә иттарткычтан чыгаралар.* Көмеш кыңгырау // Эчендә ашый торган төше булган орлыкларны, чикләвек, көнбагышны кабыгыннан арчу. *Көнбагышны, чикләвекләрне чистартып та азапланасы юк хәзер, чистартып, әрчеп саталар.* Татарстан яшьләре. *Кабак төшен чистарту*

8) Төрле кушылмалардан арындыру. *– Кызлар, бу айда премиядән мәхрүм калабыз, ахры, – диде. – Ай бетәргә нибары биш көн калды, ә мең тоннадан артык нефть чистартасыбыз бар.* М.Хәбибуллин. *Әйе, шул пычрак суны фильтрлап, хлор белән чистартып кына краннарга җибәргән эчәр суның тәнгә сихәте юк.* М.Шиһапов

9) Төрле чаралар ярдәмендә организмнан зарарлы матдәләрне чыгару. *Организмны чистарту*

10) *махс.* Урмандагы зарарланган, корыган, ауган-егылган агачларны җыю, кисү, урманнан чыгару. *Урман чистарту*

11) *күч.* Кайдан да булса дошманны куып чыгару, берәр урынны дошманнан азат итү. *Мин сиңа Усы өязен дошманнан чистартканчы отрядта калып торырга киңәш итәр идем.* В.Нуруллин. *Шушы каһарман түбә башында булып, байракны кадап төшкәннән соң, командование куполны фашистлардан чистартырга тагын бер батальон җибәрә.* А.Хәсәнов

12) *күч. сәяси* Нинди дә булса оешманы тикшереп, аны зарарлы, чит элементлардан азат итү. *[Минһаҗ:] Мине, Минһаҗетдин Гыйлаҗетдиновны, колхоздан чистартып чыгару кайсы законда, нинди дикриттә язылган икән?* К.Тинчурин

13) *күч.* Зарарлы, кирәксез, файдасыз, көчсез дип табылган нәрсәләрдән азат итү. *Аларның һәрберсе бу заманның Дон Кихотлары кебек тә тоелалар: хәшәрәтлек баскан дөньяны бераз гына булса да чистартмак уенда яналар ---.* Б.Рәхимова // Кеше аңындагы зарарлы күренешләрне бетерү, юкка чыгару. *Экстремизм агуыннан чистарту* // Кирәксез, артык нәрсәләрне бетерү, камилләштерү, чарлау. *Байтак кына язмаларда оеткы бар, яңадан язып чыгасы иде, чарларга, чистартырга кирәк, дигәнрәк фикер-теләкләр әйттем.* М.Шабаев. *Сөйләмебез – тоташ винегрет! Җәүһәр телебезне чистартырга, Рөстәм туган, берүк, ярдәм ит!* М.Сәгъдиев

14) *күч. гади с.* Берәр оешманы, берәр кешене үзен яки өен талау. *Анда да очраган бер кешенекен түгел, бәлки спекулянтларныкын һәм байрак кешеләрнекен генә чистартканнар.* В.Нуруллин. *Караклар өйне чистартып чыкканнан соң, әллә ни уфтанмадым шикелле.* А.Әхмәтгалиева

15) *күч.* Начар, түбән фикерләрне бетерү, пакь итү, сафландыру. *Тирән дра-*

*матик, еш кына трагик лиризм белән сугарылган җыр җәүһәрләребезнең ничә гасырлар буе халкыбыз күңелен агартып, чистартып, пакьләндереп, рухландырып, киләчәккә өмет уятып яңгырауларыннан һәм башка бик күп күркәм якларыннан тыш --- тагын бер мактауга лаек сыйфаты бар дип хисаплыйбыз.* Б.Рәхимова. *Аның карашынча, катарсис музыка белән кешеләрнең рухын чистарта.* К.Гыйззәтов

16) Дәрәҗәне, исемне күтәрү, начар гамәлне икенче бер гамәл белән аклау. *Миңа кияүгә чыгып, син тапланган исемеңне чистарттың.* Д.Каюмова

**Чистарта бару** Булган берен даими чистарту. *Атканнан соң көбәкнең эчен даими рәвештә чистарта барырга кирәк.* С.Поварисов. *Чишмә юлларын кар баскан, Карын чистарта барыйк.* М.Саттаров

**Чистарта башлау** Чистартырга тотыну. *Ул да, башка солдатлар кебек, итеген үзе чистартмый башлады.* Г.Исхакый. *Зөбәйдә инде кулларын камырдан чистарта башлаган иде.* В.Имамов

**Чистарта килү** Әлегәчә һәрдаим чистарту. *Башкаладагы юлларны моңарчы әйбәтләп чистарта килделәр.* Ватаным Татарстан

**Чистарта тору** Һаман-һаман чистарту; әлегә чистарту. *– Рифкать, син балык чистарта тор! – ди Шәйдулла абый.* Р.Батулла

**Чистарта төшү** Бераз чистарту; тагын да чистарту. *Күңелдә шундый өмет: тормышыбызны сәламәтләндерүгә юнәлтелгән бүгенге шифалы чаралар кешеләрнең күңелләрен дә чистарта төшәр.* Р.Фәйзуллин

**Чистартып алу** Тиз арада чистарту. *Шунда култыкта гына балыкларны чистартып та алдым.* А.Гыйләҗев. *Ул ут уйнатып самавыр куеп йөри, йөгертеп өстәл сөртә, ә дигәнче, ялт иттереп, итек чистартып ала.* В.Имамов

**Чистартып ату** *сөйл.* Бик тиз яки аннан-моннан чистарту. *Ризык мулдан кирәк булыр, дип уйлый-уйлый, газ плитәсенә ит куйдым, бәрәңге чистартып аттым.* М.Вәлиев. *Оныкбәрәңге кырырга өйрәнгәндә кулын кисмәсен дип саклап утырганчы, әби бәрәңгене тиз генә үзе чистартып ата, идән юар өчен чүпрәк, чиләк табып кулына тоттырганчы, тиз генә үзе юып чыга.* Кәеф ничек?

**Чистартып бару** *к.* **чистарта бару**. *Аның эш үзенчәлеге шунда: карны карчистарткыч эретеп, шул ук вакытта суны фильтр аша чистартып бара икән.* Шәһри Казан. *Вакытында чистартып барганга күрә, яз көне куркыныч тудырырдай кар өемнәре юк, урам башлары да кардан ачылган.* Хезмәт даны

**Чистартып бетерү** Тулысынча чистарту, барысын да чистарту. *Төрәннәрен чистартып бетергәч, Газинур сыпын турайтты, уң кулын бөеренә куеп, әле җирнең яртысына гына җитеп килгән Мисбахетдингә таба борылды.* Г.Әпсәләмов. *Чистартып бетерсәләр, күрәләр: ике йөз чиләк бәрәңге өшегән.* М.Мәһдиев

**Чистартып җибәрү** Бераз чистарту. *Себереп, чистартып җибәргәч, үләннәр калкып киткәндәй булды.* Ф.Яруллин. *Әлеге ысулларның берсен кулланганнан соң, алтын бизәнгечләрне теш щёткасы белән чистартып җибәрегез, суда яхшылап юыгыз һәм чүпрәк белән корытыгыз.* Байрак

**Чистартып кую** Алдан чистарту. *Кара әле, әти, мин, гаиләм белән бергәләп, агач ташый торган канауны да чистартып куйган идем.* К.Тәхау. *Рәхмәтулла, син берничә иярне юып, чистартып куй, ертыкларын яхшылап тегеп чык.* Р.Батулла

**Чистартып ташлау** *сөйл. к.* **чистартып ату**. *Әнисенә ярау өчен, ә дигәнче абзар чистартып ташлады, учак аслык утын әзерләп куйды, коргаксый башлаган мичкәгә урам колонкасыннан җиде чиләк су алып кереп аударды.* А.Тимергалин

**Чистартып тору** Өзлексез, һәрвакыт чистарту; әле, хәзер чистарту. *Син хатының Өммегөлсемгә әйт, морҗасының корымын ешрак чистартып торсын.* Г.Әпсәләмов. *Ике бульдозер, моторларын тәүлек буена сүндермичә, юлны көнен-төнен чистартып торсалар да, таман гына була.* А.Хәсәнов

**Чистартып чыгару** Тулысынча, тоташтан чистарту. *Бер атна дигәндә Мирвәли бакчаның эшен бетерде, якягында камышлар гына калдырып, күлне чистартып чыгарды, чишмәгә агач улак урнаштырды, аны түбә астына кертте, янына эскәмия ясап куйды.* Г.Гыйльманов

**Чистартып чыгу** Һәммәсен берәмберәм чистарту. *Шунлыктан бу китапның текстын (бәхеткә, аның наборы әле таратылмаган, исән иде) цензура яңадан бик җентекләп карап, чистартып чыгарга тиеш булды.* М.Шабаев. *Аучылар инде, бер керешкәч, Пошилар усаклыгын дүрт аяклы, азау тешле ерткычлардан, корткычлардан чипчистага чистартып чыгарга булганнар, күрәсең.* А.Хәсәнов

**Чистартып яту** *сөйл. к.* **чистартып тору**. *Көндез нинди чокырларда торба чистартып ятканын белмәделәр дә хәтта...* К.Кәримов. *Аяз беркөнне бабасы алып кайткан балыкларны чистартып яткан чагында йокысыннан уянды.* Д.Каюмова

**ЧИСТАРТУ** II *и.* 1) Берәр нәрсәне пычрагыннан, чүбеннән арындыру эше һәм процессы. *Икесе дә ындыр табагында ашлык чистартуда эшлиләр.* Н.Әхмәдиев

2) *махс.* Төрле кушылмалардан арындыру эше. *Безнең академия галимнәре нефтьне чыгару, аны чистарту, эшкәртү өстендә нык эшли.* Г.Шәйхи

3) Телне чит элементлардан, сүзләрдән арындыру күренеше. *Аларның иң зурысы – телне чистарту һәм имла мәсьәләләре.* Г.Исхакый. *Гәзит-журналлар, радио-телевидение, телне чит-ят элементлардан чистарту сылтавы белән, бик кирәкле терминнардан да баш тарталар түгелме?* А.Тимергалин

4) Берәр оешманы, илне чит, зарарлы дип табылган элементлардан арындыру максаты белән үткәрелә торган тикшерү һәм шул эшнең нәтиҗәсе; чистка. *Атеистик идеологияне пропагандалау уңае белән башланып киткән чистартулар рухи мирасыбызга әйтеп һәм сөйләп бетермәслек зыян сала.* Д.Абдуллина

5) Аерым бер урында җинаятьче, террорчы һ.б.ш.ны ачыклау, табу һәм кулга алу яки юк итү өчен оештырылган хәрби операция; *русчасы:* **зачистка**. *Тарткалаш бер генә көнгә дә тынмый: басып алучыларга каршы террорлык актлары оештырыла, яһүдләр, үз чиратында, гарәп авыл-шәһәрләрен утка, бомбага тоталар, чистартулар үткәрәләр.* Н.Шәрифуллин

6) *махс.* Урмандагы зарарланган, корыган, ауган-егылган агачларны җыю, кисү, урманнан чыгару эше. *Бу эшләр инде урман чистартуга кирә, дәүләт тарафыннан хуплана торган эш.* Н.Каштанов

**ЧИСТАРУ** *ф.* 1) Пычрактан, кердән һ.б.ш.дан арыну. *Аңа сафланып, чистарып барырга кирәк.* А.Гыйләҗев. *– Ә пальто болай ярыйсы гына чистарган... – дип тыкылдадым мин.* Ә.Мушинский

2) Чүп-чардан арыну. *Елга буйлары чүп-чардан чистарган*

3) Болганчыклыгы бетү, тону. *Бераз сабыр итәргә, инеш суының чистарып, тонып җиткәнен көтәргә кирәк.* Риваять. *Аның каравы күлләр чистарып, тирәнәеп киттеләр.* Г.Тарханова

4) Йөзен, өслеген томалап торган нәрсәләрдән арыну. *Хәзер башыңны күтәреп күккә карасаң, ул чистарган, юылган кебек зәп-зәңгәр.* Г.Әпсәләмов. *Язгы ташу сулары, җир йөзен генә түгел, әйтерсең күктәге болытларны да юып алып китте – һавалар чистарды, биегәйде.* В.Нуруллин // Өслеген каплаган нәрсәләрдән (мәс., кардан) арчылу. *Яңгыр яуса, язлар бердәм килә, Җир чистара язгы яңгырдан.* З.Мәҗитов. *--- кар сулары агып беткәч, җылы кояш нурына кызынып, кибенеп, ул тагын да ачыла, чистара ---.* Н.Фәттах

5) Чүптән, чүп үләннән арыну; чистартылу. *Овсюгтан чистарган җирдә уңыш бермә-бер артык була.* Х.Камалов. *Уңыш күзгә күренеп арткан иде шул, аннары басулар чүп үләннәреннән дә чистарды.* Ф.Зыятдинов

6) Сакал-мыекны тәртипкә китереп, битне матурлау; биттәге, тәндәге төкләрне йолку, кыру; чистарыну. *Аннан ул сакалын-мыегын кырып, чистарып чыкты.* Казан утлары

7) Йөз, биттәге бетчәләр, таплар бетү; бит төсе матурлану. *Гәүдәсе тураеп, йөзе чистарып, хәтта алсуланып киткән.* Р.Фәизов. *Тирем чистарды (шикәр ашый башлаган көнне үк, кичкә таба яңадан бетчәләр чыкты).* Идел

8) Дәвалау чаралары ярдәмендә организм зарарлы матдәләрдән арыну, төрле авыру билгеләре булган эрен, тап һ.б.ш. бетү. *Спирт белән уа-сөртә торгач, яра чистарды, ялтырап, балтыр сөяге күренде.* Р.Бәшәр. *Чистарган организм авыруларга бирешми.* Акчарлак

9) Составы ягыннан чистага әйләнү, чит кушылмалардан арыну; сафлану. *Нефть чистару*

10) Саф яңгыраш алу. *Ләкин йөрәк тибү тавышы инде чистарган, тамыр тибеше нормаль, температурасы да рәтләнгән.* Г.Әпсәләмов

11) *сөйл.* Саз, пычрак кибеп, сукмаклар төшү. *Аяк асты чистару*

12) *күч.* Дошманнан, зарарлы, кирәксез элементлардан азат ителү. *Бүтәннәре батырларча һәлак булдылар, кайсылары сугыш кырларына китте: дошманнан чистарган җирләрне сөрергә һәм башкага.* Ә.Баянов. *Көтүдәге аксактуксак биш-алты сарыкны куып җибәрүдән чистарабыз гына.* В.Имамов

13) *күч.* Чит тел сүзләреннән, чит тел йогынтысыннан арыну. *Аның тәрҗемәләре (аларның саны йөзгә якын) гарәп, фарсы телләре йогынтысыннан шактый чистарган булып, шул замандагы гади халык теленә мөмкин кадәр якынлаштырып эшләнгәннәр.* М.Мәһдиев

14) *күч.* Рухи яктан сафлану, начар, түбән уй-фикерләр, омтылышлар юкка чыгу. *Ул чыганакка килгән кешенең дә җаны чистара, күңеле сафлана.* Ш.Галиев. *Чәчләре, битләре буйлап аккан яңгыр суыннан Ихтыярның уйлары да чистара, тәртипкә килә баргандай тоелды.* Р.Вәлиев. *Бозык адәм чистарганчыга кадәр берничә газаплы тормыш яши.* Фән һәм тел

**Чистара бару** Торган саен чистару. *Шушы малай аяк астымда ешрак ышкылган саен, ботинка-туфлиләрем чистара бара.* Ф.Баттал

**Чистара башлау** Чистару билгеләре күренү. *Ниһаять, күк йөзе чистара башлый, кара болытларның калын пәрдәсен хәнҗәрдәй нурлары белән кисәкисә, ярымай пәйда була.* И.Диндаров. *Гомер буе шәмәхә карандаш белән рәсем ясап, авызын, ияген, кулын буяп бетерә торган Илфат та чистара башлады.* Р.Газиз

**Чистара төшү** Бераз чистару; тагын да чистару. *Барысы да шул, тик һәр җирендә чистара төшкәнлек, ыспайланганлык, калыпланганлык сизелә.* М.Әмир

**Чистарып алу** Беразга чистару; тиз генә чистару. *Чистарып алганда була торган канәгатьлек белән, шома аякларен сыпыра-сыпыра, Моратбакый сәкегә килеп ятты.* М.Галиев

**Чистарып бару** Торган саен, һаман чистару. *Гаҗәп, шуның кадәр зур төзелешләр гөрләгән, көннән-көн матурланып-чистарып барган һәм, иң мөһиме, Идел ярында урнашкан Казаныбызда кызынып та, су да кереп булырлык урыннар бөтенләй юк икән бит.* Шәһри Казан

**Чистарып бетү** Тулысынча чистару. *Сул кулы белән күкрәгенә кысып торган сиреньнәре башта басма такталарына, аннары, берән-сәрән генә салынып, инешнең әле чистарып бетмәгән болганчык суына коелдылар.* Г.Кашапов

**Чистарып калу** Нәрсәнең дә булса ахырында чистару. *Дөнья чистарып калгандай була.* Г.Каюмов. *Туган йортындагы һәр мизгел җанына савап кебек; күңел сөремнәре тарала, үзе дә сафланып, чистарып калгандай тоела.* З.Хөснияр

**Чистарып килү** Акрынлап чистара башлау. *Җил тәмам тынган, күк йөзе дә болытлардан чистарып килә.* Г.Әпсәләмов

**Чистарып китү** Билгеле моменттан чистара башлау; берникадәр чистару. *Яңгыр ява, яңгыр ява, Рәхәтләнеп, биеп ява, Шатландырып, шаулап ява, Күр, чистарып китте һава!* Ш.Галиев. *Дога кылсам туган нигеземдә, Җаным китә гүя чистарып.* Р.Зәкуан

**Чистарып тору** Даими чистару; әледән-әле чистару. *Һәр 10–12 сәгать саен бактерияләр үлеп, су үзеннән-үзе чистарып тора икән.* Татарстан яшьләре. *Кортлар тыз-быз йөреп торганга, өй эчендә һава да даими рәвештә чистарып тора.* Безнең гәҗит

**ЧИСТАРЫНУ** I *ф. кайт. юн. к.* **чистару**. *Юын, чистарын да, бисмилләңны әйтеп, белгән догаңны укы.* Г.Галиева. *Тузанга батып, пычранып беткән киемнәрен салып ыргытты да, ягылмаган мунчага барып, юынып, чистарынып чыкты.* Г.Гыйльманов

**Чистарына бару** Торган саен чистарыну. *Сез «яман» дип сөйләгәннәр саен, Чистарына бара үткәннәрем.* К.Булатова. *Ниһаять, Йосыфның һаман ачыла, чистарына барган күңеле ул сүзне эзләп тапты ---.* Г.Гыйльманов

**Чистарына башлау** Чистарынырга тотыну. *Тик кеше кайчан да булса чистарына башларга тиеш.* Ф.Яруллин

**Чистарына тору** Әлегә чистарыну, алдан ук чистарына башлау. *Гөнаһлардан чистарына торыгыз!* Безнең гәҗит

**Чистарына төшү** Бераз чистарыну; тагын да чистарыну. *Мәче аңа ияләшеп китте, көннәрен гуава күләгәсендә йоклап уздыра торган булды, тәненә бераз ит кунды, чистарына төште.* Казан утлары

**Чистарынып алу** Тиз генә чистарыну; вакытлыча чистарыну. *Кондызлар, юынып, чистарынып алгач, яр буендагы таллардан һәм үләннәрдән авыз иттеләр.* К.Тәхау. *Әйдә, кызым, тиз генә без дә чистарынып алыйк, күшеккәнсеңдер.* Ф.Яруллин

**Чистарынып бетү** Бөтенләй чистарыну. *Гәрәй морза, мәшһүр оперettадагы җыр көенә сызгырынгалап, кырынып, чистарынып бетте дә, чигәяңакларын хушбуйлап, мыегына фиксатуар сөртеп, аның очларын югарыга таба тырпайтыбрак бөтереп куй-

*ды ---*. М.Галәү. *Чистарынып беткәч, чебен очып китә*. Р.Батулла

**Чистарынып җитү** Тиешенчә чистарыну. *Шуның өчен кеше үз-үзен начар тойгылардан азат итеп, психологик яктан чистарынып җиткәч кенә, физик мәгънәдә авырудан котыла ала.* Кәеф ничек?

**Чистарынып калу** Ахырда, соңында чистарыну. *Гайбәт сөйләгәндә, син бүтәннәрне каралтып, үзең парлы мунчадан чыккан кебек чистарынып каласың.* М.Галиев. *Тәмам чистарынып калгач, әле кайнар, әле салкын су белән берничә тапкыр коенып алды, ә соңыннан, таманча суга хуш исле кушылмалар сибеп, ваннага сузылып ятты.* М.Кәбиров

**Чистарынып китү** Билгеле бер моменттан башлап чистарыну. *Дөрес микәнни, күңелең бәхеттән тутыга башласа, бәладән соң чистарынып китә, диләр...* Ф.Яхин. *Сүз дә юк, өмәләрдән соң тирә-юнебез чистарынып китә.* Яшел Үзән

**Чистарынып тору** Даими чистарыну; әле чистарыну. *Шуңа күрә даими дога укырга, чистарынып торырга кирәк.* Ватаным Татарстан

**ЧИСТАРЫНУ** II *и.* 1) Төрле чистарту, юыну эшләре. *Башланды чистарыну, төзәтенү, мичләр, моржҗалар, мунча мичләре агарту, чаршау, чыбылдык, күлмәкләр тегү, китте тазарыну-юыну, киенү-ясану.* Г.Бәширов

2) Психологик бушану; эчке тазарыну күренеше, катарсис. *Ч.Айтматов әсәрендәге трагик язмышлы Бостан укучыны даими рәвештә «нәрсә булыр инде» дип көтү хәлендә тота, Аристотель терминын кулланып әйткәндә, аның өчен катарсис (чистарыну) кичерү чыганагы хезмәтен үти.* К.Гыйззәтов

**ЧИ́СТКА** *и. рус сәяси* 1) Берәр урында, гадәттә, оешмада, зарарлы һәм кирәкмәгән чит элементлардан арыну максаты белән үткәрелә торган тикшерү; чистарту. *Заманыбыз – чистка заманыдыр ---*. Һ.Такташ. *Алай гына да түгел, ул бичараны һаман каккалый да суккалый тордылар, чистка (чистарту) аша да үткәрделәр, җитмәсә, җидегәнчелектә гаепләп, утыртып та чыгардылар.* Ә.Еники

2) Гомумән кирәкмәгән, ят, зарарлы дип табылган нәрсәләрдән азат итү күренеше. *Шул югарыда китерелгән мисаллардан ук күренгәнчә, мәкальләргә чистка ясау күбесенчә Марр теориясе нигезендә, алардагы аерым берәр сүзгә «сыйнфый» дип карауга гына корылган механика булуы ачык.* Н.Исәнбәт. *Безне җыеп, үзенә күрә чистка үткәрә.* Т.Миңнуллин

**ЧИ́СТЫЙ** *кис. рус сөйл.* **1.** Чын, нәкъ. *Теге кунак бабай безне алдаган, чистый юлбасар икән ул.* Г.Гобәй. *Тормышны өйрәнегез, тормышны өйрәнегез дип, һаман колагыгызга тукып торалар, ә сез һаман чистый идеалистлар икән, Николай Максимович.* Г.Әпсәләмов. *Тел дә бар инде үзендә! Чистый кычыткан, өтеп кенә ала.* Г.Бәширов

**2.** *рәв. мәгъ.* Тәмам, бөтенләй. *Чистый туеп беттем инде үзләреннән, төсләрен дә күрәсем килми.* Г.Камал. *Бер тотынгач, бөтенләй сугып бетерәсе калган, чистый кара туфракка калдырып!* Г.Бәширов

**3.** *ы. мәгъ.* Соклану, җирәнү, канәгатьсезлек һ.б.ш. хисләрне белдерә. *И кыланчык! Бәяңне күтәрәсең, чистый.* Н.Гыйматдинова

**ЧИТ** I *и.* 1) Берәр предметның кырые, кырый. *Мин, инде тәмам тәшвишләнеп, урындык читенә килеп утырдым.* А.Тимергалин. *Хатын, бөкләнгән аякларының ойый башлавын тоеп, аларны арба читенә салындырып утырды.* А.Әхмәтгалиева

2) Берәр предметның яны, янындагы урын. *Ул замандагы устав буенча, укчылар чек итеп бәрелүгә, уң кул ялт итеп козырек читеннән ычкынырга тиеш.* Ә.Маликов // Берәр нәрсәнең үзәктән ераграк өлеше. *Ул ара каяндыр бик күп кешеләр килеп чыктылар, мине, этә-төртә, бөтенләй бер читкә үк чыгардылар.* А.Алиш

3) Эшләпә кебек баш киемнәренең ян-яктагы горизонталь өлеше, кыры. *Юл буе сөйләшмәделәр, төшкәч, бер-берсенә күтәрелеп карамыйча, эшләпә читләрен калкытып алдылар...* А.Гыйләҗев

4) Иреннәрнең, күзләрнең почмагы. *Җакшылыковның ирен читләре тартыша башлады.* А.Хәлим. *Рәфис ирен читен кыймылдатып елмаеп куйды.* А.Вергазов

5) Торак пункт, урман һ.б.ш. нәрсәләрнең кырыендагы җир, урын. *Ул каланың иң читендә тора.* А.Гыйләҗев. *Минәт, аның саен котырып, уҗым читендәге чирәмне бармаклары белән аралый-аралый, тезләрендә үрмәли бирде.* А.Вергазов // Чокыр, яр, елга кебек нәрсәләрнең кырые. *Басып торам текә яр читендә, Карыйм тирә-якка ---*. А.Алиш. *Көймә яр читенә килеп туктады.* Б.Ислам

6) Юл, урам һ.б.ш. нәрсәләрнең буйга сузылган һәр ике яктагы кырые. *Һашимов, үзен биләп алган каршылыклы уйлардан арынырга тырышып, зур тизлектә артка йөгерүче таш йортларга, урам читенә утыртылган өрәңге агачларына карап бара башлады.* А.Вергазов. *Малай, көрәкләрен җилкәсеннән алып, сукмакның читенә чыгып басты һәм «кәҗә тәкәсе»нең узып китүен сабыр гына көтә башлады.* А.Гыймадиев

7) Күк, офык кебек зур мәйданның, пространствоның кырыен чикли торган сызык. *Әнә зәп-зәңгәр офык читеннән, көлә-көлә, алтын кояш та күтәрелә.* А.Алиш. *Хакыйкый таң исә яктылык күк читеннән таралып җәелә башлагач була.* А.Тимергалин

8) Берәр предметның ян өлеге, ян ягы. *[Гыймадиның] башында чите камалы мескен бүрек, аягында оекчабата.* Г.Ибраһимов // Савытның ян өлеге, кырые. *Шулай ук сүзсез генә чәй эчтеләр алар – өйдә иреннәрнең чынаяк читендәге чепелдәүләре генә ишетелә иде.* А.Хәлим. *Дустым хисләрен яшереп кала алмый, кулындагы калагы чынаяк читен зеңләтә.* А.Мансуров

◊ **Читтән торып** 1) Дәрес-лекцияләргә даими рәвештә йөрмичә, эштән аерылмыйча. *Физика-математика бүлегендә читтән торып укыйм.* А.Тимергалин. *Читтән торып, гел бишлеләргә генә укып, финанс институтын тәмамлаган.* А.Хәсәнов; 2) Турыдан-туры аралашмыйча. *Читтән торып булса да минем родичлар белән таныш.* А.Гыйләҗев

**ЧИТ** II *с.* **1.** 1) Туган яки якын булмаган, туганлык мөнәсәбәтләре белән бәйләнмәгән; бөтенләй ят. *Ярар, чит кеше кадалсын әле, монда үз хәлем хәл.* А.Алиш. *Бу сүзләрне Гали хәзрәтләре үзенә каршы сугышкан бер чит батырга әйтә.* А.Тимергалин

2) Туган җирдән, даими рәвештә яшәгән урыннанерактагы. *--- авылда ныклап төпләнгәнче, байтак еллар чит җирләрдә йөрергә туры килде миңа.* В.Нуруллин. *Зәйнәп аны танымый, ул чит авылдан китертелгән сатучы иде.* А.Гыйләҗев

3) Башка сыйныфка, коллективка һ.б.ш. караган; *киресе:* **үз**. *Җә-ә инде, нәрсә ялындырасың, күрсәт инде, бирегә чит кешеләр юк бит.* А.Гадел

4) Башка илгә караган, башка дәүләтнеке булган; башка халыкныкы

булган. *Мәдәниятебезгә чит йогынтылар мәсьәләсе – зур һәм катлаулы проблема.* А.Тимергалин. *Миңа чит көйләр, чит оҗмах бакчаларына караганда халкыбызның ачы сүзләре, халкым мәхәббәте белән сугарылган кырыс туган ягым якынрак.* А.Нәҗми

5) Башка, таныш булмаган. *Шуннан соң ул инде чит авазларны ишетмәс булды.* А.Толстой

6) Алынма, ана теленә карамаган, ана теленеке булмаган. *Нинди халыкның сүзләре күп кергән (мәсәлән, нинди чит сүзләр бик еш истигъмаль кылына)?* Гали Рәхим

7) *махс.* Нәрсәнең дә булса үз состав өлешенә карамаган, шул ук токымнан булмаган. *Бер тонна чималда нибары бер генә грамм чит катнашма була.* М.Зарипов. *Бу мәгълүматларга нигезләнеп, известьташта ничә процент чит катышмалар булганлыгын ничек белергә?* Химия

8) *мат.* Бирелгән тигезләмәне канәгатьләндерми торган. *Тигезләмәнең кисәкләрен квадратка күтәргәндә, чит тамырлар дип йөртелә торган тамырларның керүе мөмкин.* Алгебра

9) *лингв.* Автор сөйләме булмаган, башка зат сөйләменә караган. *Текст синтаксисы эчендә автор тезем, чит сөйләм мәсьәләләрен дә ачыклый.* Татар грамматикасы

10) *күч.* Асылы, эчтәлеге, төп сыйфатлары белән кемгә яки нәрсәгә дә булса капма-каршы булган; кемгә яки нәрсәгә дә булса хас булмаган. *Ул шул вакытта ук аның каршылыклы, кеше табигатенә, рухи яшәешкә чит булган эклектик асылын дөрес тоеп, сиземләп ала һәм, табигать белән кешелек җәмгыятенең эчке үсеш закончалыкларына таянып, адәм баласының күңел дөньясына үтеп керә.* А.Тимергалин

11) *күч.* Күңел кабул итә алмаган, ят тоелган. *Ире аңа чит иде.* А.Вергазов

**2.** *и. мәгъ.* 1) Туганлык мөнәсәбәтләре белән бәйләнмәгән зат, ят кеше. *Тик яхшыдан күрен чит күзенә.* В.Ильясов. *Акча күп, ул читләр кулында.* Б.Рәхимова

2) Башка, туып үсмәгән җир; ят, еракташы җир. *Әтиең, мәрхүм, гомере буе чит дип саташты.* А.Гыйләҗев. *Белемен камилләштерү, ислам мәгърифәте үзәкләре белән якыннан танышу һәм шул нигездә татар мәдрәсәләре эшенә реформа үткәрергә әзерләнү өчен, ул яңадан читкә чыгып китә ---.* А.Тимергалин. *Мә, кошчык, бер язу – Оч әле читләргә, Тапшыр бу хатымны ---.* Б.Ибраһим

3) Башка дәүләт, ят өлкә; башка халык. *Кирәк түгел миңа читләр җире, Кирәк түгел дөнья байлыгы.* Ә.Исхак

◊ **Чит авыздан** Башкалар аша. *Әйтми торырга да ярамый, барыбер хәбәр килеп җитәчәк, чит авыздан ишеткәнче, хатыныңнан ишетсен ---.* А.Гыйләҗев. **Чит итү** *к.* **чит күрү**. *Гәрчә Әнәснең бер гаебе булмаса да, башкалар рәнҗеткән күңелем аны чит итә, кыерсытырга гына теләп тора, һаман тынычлана алмыйм.* А.Гыйләҗев. *Үзенең тормыш шартларын тасвирлап күрсәтте, малайның да аны чит итмәвен сөйләде.* А.Фәләх. **Чит кагу** *к.* **чит күрү**. *Ничек инде үз туганыңны чит кагасың?* А.Гадел. **Читкә чыгу** Күпләргә мәгълүм булу, таралу. *Алар Тютеев белән күзгә-күз генә сөйләшкәннәр иде, ничек итеп бу сүз читкә чыккан икән?* Г.Әпсәләмов. *--- әмма бу дуслыкның эчке серләре икесе арасыннан берчакта да читкә чыкмый!* А.Гыйләҗев. **Чит күзгә** Берәр нәрсә белән таныш булмаган кешегә, нәрсәне дә булса якыннан белмәгән кешегә. *Анда чит күзгә ансат кына ачылмый, әмма һәрдаим үзенә җәлеп итеп сокландыра, үзен-үзе сөйдерә һәм шул ук вакытта гаҗәпләндерә торган ниндидер бетмәс-төкәнмәс, армас-талмас тылсымлы көч бар иде.* Г.Бәширов. **Чит күрү** Үз итмәү, якын итмәү. *Ләкин Шәнгәрәй хатыны Рәгыя гомер барынча кочегарны чит күрә иде.* Г.Ибраһимов. *Син аларның күңелләренә башта ук керергә тырыш, югыйсә алар сине чит күрәчәкләр.* Г.Әпсәләмов. **Чит планетадан килгән** Бик нык аерылып торган; бик сәер булган. *--- ниндидер эш белән каядыр ашыгучы берсе яшь, икенчесе олырак кыяфәтле хатын-кызлар аңа, чит планетадан килгән кешегә карагандай, кызыксынучан караш ташлап үттеләр.* А.Вергазов. **Чит тибү** *к.* **чит күрү**. *Яшьтәшләре чит типми кызны.* А.Хәйретдинова

**ЧИТӘН** *и.* **1.** Чыбыктан үреп ясалган киртә. *Вак тал чыбыкларыннан үрелгән утыртма читән өстеннән ишегалдына сузылган ботакларда зурзур алмалар күренә.* А.Гыйләҗев. *Күршеләр Мөршидәттәй, Мөслимәттәй Кер эләләр читәнгә. Өмет баглап килачәккә, күз салалар үткәнгә.* Г.Афзал

**2.** *с. мәгъ.* Чыбыктан үреп ясалган. *Әбекәйне зурлап, авыл урамнарын урап барасы читән тарантаска Кашканы бик көязләп җикте безнекеләр.* Г.Галиева. *Авыл әллә ни үзгәрмәгән дә кебек: салам түбәле йортлар, читән коймалар да нәкъ элеккечә.* Г.Әдһәмова. *Шыгырдавык читән креслоларга утырган пассажирлар алсу-яшел җирнең акрынлап кына аска төшкәнен күзәтеп баралар.* А.Толстой // Шулай үрелеп һәм балчык сыланып ясалган. *Ярсып торган айгырны алама читән абзарда саклап тотып булмый шул.* С.Поварисов

**ЧИТӘНЛЕ** *с.* 1) Читәне булган, читән куелган. *Җимерек читәнле, каралып беткән салам түбәле ташландык бер каралтыга җитүгә, Васил сорап куйды: – Монысы нәрсә тагы?* С.Рафиков

2) Як-яклары талчыбыктан үреп ясалган. *Түрдә – тәрәзә буенда – читәнле бала караваты тора.* Р.Зәйдулла. *Анда, куыш әйләнәсендә, Акмырза сабанга үгезләр җигә, Муллагали белән урядник биек читәнле тарантас һәм кыңгыраулы атлар тирәсендә чуала иде.* Н.Яһудин

**ЧИТӘНЛЕК** *с.* **1.** Читәнгә ярый торган, читән тотарга китә торган. *Читәнлек чыбык*

**2.** *и. мәгъ.* Читәнгә китә торган чыбык. *Урманда бригадир булып эшләүче Микиш дәдәй үз бригадасына эшкә алып барып, бер кустарникка илтте, менә шушыны чистарт, читәнлеккә яраганын аерып куй, диде, алып кайтырга да булышты.* Туганайлар

**ЧИТӘ́Н-ЧЫБЫК** *җый. и.* Читән тотуга яраклы чыбык-чабык. *Хәтерлисеңме, Җамал, минем тавыкларым читән-чыбыктан үргән бер кетәктә яшиләр иде.* А.Гыйләҗев

**ЧИТЕК** *и.* Йомшак, элек сәхтиян күннән тегелгән, юка олтанлы, кунычлы аяк киеме. *Бер почмакта берничә сукыр Коръән укый; вә икенче почмакта аксак-туксак адәмнәр читек тегеп утыралар.* Г.Ибраһимов. *Әби башына чуклы ефәк шәл бәйләп, билле бәрхет камзул кигән, аягында бизәкле кызыл читек иде.* А.Тимергалин

**ЧИТЕ́К-БАШМАК** *и.* 1) Читек өстенә киелгән башмак, берьюлы киелгән читек һәм башмак. *Аягыңда читек-башмак, Башыңдадыр ак калпак ---.* Г.Кандалый. *Аягында тамбурлы читек-башмак, чәче вә күзләре, вә кашлары ялтыравык кара, йөзе нурлы, кызгылт ак, борыны кечкенә вә гүзәл.* М.Акъегет

2) Читек, башмак ише аяк киемнәре. *Чигүле читек-башмаклар, китап-*

*альбомнар, йөзек-беләзекләр һәм башындагы бүреген дә куеп, кечкенә генә күргәзмә дә ясаган.* М.Маликова. *Монда матур кием-салымнар тегәләр, читек-башмак кияләр, алар үзләренең эшләнешләре белән бөтен дөньяга билгеле.* Р.Рахман

**ЧИТЕ́К-КАТА** *җый. и.* 1) Берьюлы киелгән аяк киеме буларак читек һәм ката. *Габдрахман ак илтер бүректән, читек-катадан.* А.Расих

2) *к.* **читек-башмак** (*2 мәгъ.*)

**ЧИТЕ́К-КӘВЕШ** *җый и.* 1) Берьюлы киелеп, бербөтен аяк киеме тәшкил иткән читек белән кәвеш. --- *бүлмә ишеге ачылды, аннан аягына читек-кәвеш, өстенә иске җөббә, башына тирән бүрек кигән бер мулла килеп керде.* Г.Ибраһимов. *Аякларында чигүле сафьян читек-кәвеш.* А.Хәсәнов

2*) к.* **читек-башмак** (*2 мәгъ.*)

**ЧИТЕ́К-КӘВЕШЧЕ** *и. иск.* 1) Читек һ.б.ш. аяк киеме тегүче

2) Читек, кәвеш белән сәүдә итүче сәүдәгәр. *Шакир хаҗи – читек-кәвешче, тәбәнәк гәүдәле, чиктән тыш юан корсаклы, второй гилди купец.* Г.Камал

**ЧИТЕ́К КҮБӘЛӘГЕ** *и. диал.* Читекнең үкчә турысындагы өлгесе

**ЧИТЕ́К-ЧАБАТА** *җый. и.* Читек, чабата ише аяк киемнәре. *Сез бит җирле халыкның тарихын күзгә карап таптыйсыз, талыйсыз, аны читек-чабатага гына кайтарып калдырасыз.* Ф.Бәйрәмова

**ЧИТЕКЧӘН** *рәв.* Читек кигән килеш, читек киеп. *Әтекәемнең гурничасында йөри идем лә читекчән генә.* С.Баттал

**ЧИТЕКЧЕ** *и.* Читек тегүче; читекләр белән сәүдә итүче. *Ул кибетче малайларга, читекче, кәвешчеләргә ак яка киертте ---.* Гали Рәхим. *Менә тагын читекчеләр – безнең шикелле инә белән кое казучылар.* Г.Бәширов

**ЧИТЕН** *с.* **1.** 1) Башкару өчен зур көч, тырышлык һәм хезмәт таләп итә торган; авыр. *Чабата үрү башта миңа бик читен, баш җитмәстәй эш булып күренгән иде.* В.Нуруллин. *Әйди данлаган мәшһүр татарларның һәммәсен санап чыгу – читен эш.* Б.Камалов

2) Чишү, аңлау, хәл итү өчен акыл, тәҗрибә, хәйлә сорый торган; кыен. *Ләкин бер читен мәсьәлә бар: бу алтыннарны ничек итеп кулга кертергә кирәк?* Г.Камал. --- *аларның диннәрен дә бер системага салу шактый читен бер эш булды.* Гали Рәхим. *Белмим, исемнәрне тәрҗемә итүе – читен нәрсә.* Г.Әпсәләмов

3) Кыенлыклар, авырлыклар белән үтә торган. *Иң читен вакытларда да аһ ормый, күңелен төшерми.* В.Нуруллин. *Берүк мине сүздән арала, читен хәлдә калдыра күрмә.* А.Гыйләҗев

4) Четерекле; авыр, катлаулы. *Ләкин, үзең беләсең, ул – бу яктан бик читен кеше, күндерү кыен.* М.Җәлил

5) Күңелгә авыр тәэсир итә торган, кабул итүе, кичерүе авыр булган. *Нахак сүз ишетүдән дә читен нәрсә юк Фәләх өчен.* В.Нуруллин. *Кайчандыр үзе зур җитәкче булып, коллектив белән идарә иткән кешегә соңыннан урынбасар сыйфатында йөрү – үтә читен хәл бит.* В.Имамов. *Әллә нинди уңайсыз, читен бер тынлык иде бу.* Г.Әдһәмова

6) Матди яктан авыр, уңайлыклары, шартлары булмаган. *Безнең Ташчы шул минуттук зур бай булды, Азапланган читен тормыш уңай булды.* Г.Тукай

**2.** *и. мәгъ. сөйл.* Авырлык, кыенлык, читенлек. *Миллион теләк, авыр танк кебек, һәр читенне таптап үткәндә, Безнең домна әкрен, әкрен бара.* Ш.Маннур

**3.** *рәв. мәгъ.* Авыр, төрле кыенлыклар күреп. *Шәйхразый күрше читен яшәде, авыр кеше, әмма аның да хәер-фатихасын чит итмәскә кирәк.* А.Гыйләҗев

**4.** *хәб. функ.* 1) Кыен, мөмкин түгел. *Тормыш юлы борылмалы да сырылмалы, кая илтеп чыгарыр ул – алдан әйтүе читен.* Ә.Еники. *Чигенергә дә куркыныч, алга атлавы да бик читен.* Г.Әпсәләмов

2) Үзеңне начар хис итү турында. *Миңа үзем кылган нәрсәләр өчен бик тә читен һәм оят.* А.Нәҗми

◊ **Читенгә калу** Авыр булу. *Салкын окопларда көне буе җан саклап тору да бик читенгә калды.* М.Гали

**ЧИТЕНӘЙТҮ** *ф. сөйл. к.* **читенләштерү**. *Хәлне читенәйтү*

**ЧИТЕНӘЮ** *ф. сөйл. к.* **читенләшү**. *Эш читенәю*

**ЧИТЕНЛӘНҮ** *ф. сөйл. к.* **читенләшү**

**ЧИТЕНЛӘШТЕРҮ** *ф.* Читен итү, авырлаштыру, кыенлаштыру. *Хикмәт монда бер мине мәхрүм итүдә генә түгел иде – стипендиясез калу минем хәлемне бик нык читенләштерәчәк тә иде.* Ә.Еники. *Шуның өстенә Мәрҗәни хезмәтенең гарәп телендә булуы файдалануны читенләштерә.* Т.Әйди

**Читенләштереп җибәрү** Тагын да читенләштерү; көтмәгәндә читенләштерү; бераз читенләштерү. *Бу хәл эшне шактый читенләштереп җибәрде.* Г.Әпсәләмов

**ЧИТЕНЛӘШҮ** *ф.* Авырлашу, кыенлашу. *Аяк-кул авырайды соңгы өчдүрт елда. Йөрүләр читенләшә.* З.Зәйнуллин. *Илдарга хезмәт итү бер дә җиңел түгел иде, ә соңгы вакытта бөтенләй читенләште.* И.Хуҗин

**Читенләшә бару** Торган саен ныграк читенләшү. *Вакыт үткән саен, Искәндәрнең хәле читенләшә бара.* Г.Әпсәләмов. *Татлы ризык табу көннән-көн читенләшә барды.* В.Имамов

**Читенләшә башлау** Читенләшү билгеләре күренү. *Бераздан тын алырга читенләшә башлады.* С.Зыялы

**Читенләшә төшү** Бераз читенләшү; тагын да читенләшү. *Шуның нәтиҗәсендә бу фактларның чик араларын билгеләү мәсьәләсе тагын нечкәрде, тагын читенләшә төште.* Г.Алпаров. *Ә менә миңа аның – колхоз председателенең – телен аңлау хәзер бераз читенләшә төшкән икән.* М.Әмир

**Читенләшеп китү** Соңгы арада читенләшү. *Минем хәл тагын читенләшеп китте.* Ә.Еники. *Совет кешеләренең хәле бик читенләшеп китте бит менә.* Г.Хуҗиев

**ЧИТЕНЛЕК** *и.* 1) Читен (*1–2 мәгъ.*), кыен булу. *Шулай ук мөндәриҗәләрнең бәгъзы урыннарда өзелә баруы, киналарнең аңларга читенлеге сезгә ят тоелыр.* Һ.Такташ. *Гарәпчәне бераз читенлек белән, тотлыга-тотлыга, бик акрын укый иде.* Гали Рәхим

2) Авыр, кыен хәл, авырлык, кыенлык. *Ул шул читенлектә, шул начарлыкта өч еллар буена анасын эзләп йөрсә дә, беркем дә әнкәсе турында хәбәр белми иде.* Ш.Әхмәдиев. *Бер читенлеге бар: иптәшләр кәйрәк минем.* А.Гыйләҗев. *Мин, тыныч кына, сиңа да, авыл халкына да читенлек китермичә, соңгы минутымны үз почмагымда көтәрмен инде.* Д.Салихов

3) Комачау, киртә. *Ләкин биек заводның батыр эшчеләр коллективы, партия җитәкчелегендә, корыч бердәмлек белән, бу читенлекләрне бөтенесен ерып чыга.* Ш.Камал. *Кытайга чыкканда да ни казакълар тарафыннан, ни кытайлар ягыннан читенлек күрмәдек.* Р.Батулла

**ЧИТЕНСЕНҮ** *ф.* Тартыну, уңайсызлану, ятсыну, беркадәр оялу. *Ачыктан-ачык сорасам да, Азат туры гына җавап бирмәде, читенсенде,*

*ләкин аның оялчан елмаюында ниндидер сер бар сыман тоелды.* А.Тимергалин. *Нәрсә кирәк булса да, читенсенмә, сора.* А.Мансуров

**Читенсенә башлау** Читенсенергә тотыну. *Фатир сорап мондый йортка кергәненә дә читенсенә башлады Мотгәрәй.* Ш.Шәйдуллин. *Гади кибетче чагында читенсенә башлаган идем.* А.Гыйләҗев

**Читенсенеп калу** Кинәт читенсенү. *Крестьян йортының алты кешелек бүлмәсенә кереп, андагы ят хатыннарны күргәч, читенсенеп калган иде.* М.Маликова. *Хәсрәтле хатын бу катгый сораудан читенсенеп калгандай булды.* Р.Камал

**Читенсенеп китү** Читенсенә башлау. *Бөтен күзләрнең үзенә текәлгәнен күргәч, Закирҗан читенсенеп китте, аның маңгаена бөрчек-бөрчек тир бәреп чыкты.* И.Хәйруллин. *Шактый вакытын китапханәдә имтиханнарга әзерләнеп үткәргәннән соң, моңсуланып, кайтырга чыккан гына иде, арттан кемдер дәшүен ишетеп борылса, Мансур Ибраһимовичны күреп, читенсенеп китте.* Х.Ширмән

**Читенсенеп кую** Кинәт яки берникадәр читенсенү. --- *Сәвия кызы өчен доктор каршында бераз читенсенеп куйды.* Г.Бәйрәмова. *Мин читенсенеп куйдым.* А.Мансуров

**Читенсенеп тору** Әле читенсенү; берникадәр вакыт читенсенү. – *Апаем, баядан бирле әйтергә читенсенеп торам,* – *диде ул.* Р.Кәрами. *Гаепле кеше кебек, аның күзләренә карарга читенсенеп торды.* З.Кадыйрова

**ЧИТКӘ** *рәв.* Берәр нәрсәдән төп юнәлештән бер яккарак, арырак. *Алгебра дәфтәрендәге «а»лар, «б»лар, күз алдында ниндидер йөзләргә әверелеп, мыскыллы елмаялар шикелле тоелды – малай ачу белән дәфтәрне читкә шудырды.* А.Әхмәтгалиева

◊ **Читкә алып кереп китү** *к.* **читкә бору**. *Сөйләшүне --- читкә алып керәсең дә китәсең.* А.Хәлим. **Читкә бору** Төп сүздән, темадан, уй-фикердән икенчесенә күчү, игътибарны башкага юнәлтү. *[Рәшат:] Күрә торып безнең сүзгә кысылмасын! Син читкә борма.* А.Гыйләҗев. **Читкә кагу** 1) Читкә җибәрү, куу. *[Үгез] Бүрене сөзә һаман, читкә кага.* М. Гафури; 2) Кыерсыту, рәнҗетү. *Петухов аны һаман якын итеп йөри, читкә какмый.* В.Имамов. *Әрләмәгез берүк баланы! --- Ялгышса да, читкә какмагыз, Һәр эшеннән гаеп тапмагыз.* В.Хәйдәрова; 3) Кабул итмәү. *Читкә кактым иблисләрнең Котыртуын, азуларын ---.* И.Юзеев. *Барчагызга да рәхмәт, минем чакыруны читкә какмыйча, ярминкәгә килгәнсез.* А.Гадел; 4) Буш итү; ташлау. *Әй, зинһар, юк сүзне сөйли күрмә, эш була калса, боерган булса, сине читкә какмыйбыз инде.* Г.Камал. **Читкә китү** Төп мәсьәләдән ерагаю, тайпылу. *Гәпне күңелсез хатирәләргә таба бормас өченме, бүгенге көн темасыннан читкә китмәскә тырыштым.* А.Тимергалин. **Читкә кую** 1) Берәр эшне туктатып, бүлдереп тору. *[Ләмига:] Шуңа күрә безгә, Көнбатыш уеннарын һәм күңелле романнарын бер читкә куеп торып, балаларыбызны эшмәкәрлек рухында тәрбияләргә, аларны сәүдәгә, коммерциягә, фәнни нигезгә корылган авыл хуҗалыгы хезмәтенә өйрәтергә кирәк.* А.Тимергалин; 2) Нәрсәдәндер баш тарту, оныту, ваз кичү. *Оятыңны читкә куеп, мине тыңла.* А.Гыйләҗев. **Читкә тарату** *к.* **читкә чәчү**. *Күргәннәреңтурында читкә таратма.* А.Гыйләҗев. **Читкә тибәрү** *к.* **читкә кагу**. *Уллары аның, үзе кебек җәфа чигеп, такытокыда укырлар, таяныр әтиләре булмас, аларны ятим-ялпы дип кагарлар, читкә тибәрерләр.* А.Гыйләҗев. **Читкә тибү** *к.* **читкә кагу**. *Халык аларны көннән-көн ныграк читкә тибә.* Г.Гыйльманов. *Матур итеп җырлаган, моңгахискә мөлдерәмә тулы Дилемма гармунчы егетне читкә тибү түгел, үзе үк, Ралиф башка берәрсенә карый күрмәсен иде, дип көйде.* З.Мурсиев. **Читкә чәчү** Яшерен мәгълүматны, серне башкаларга сөйләү, тарату. --- *Гөлнарага серен читкә чәчәргә ярамаган ---.* А.Гыйләҗев. *Тешем кысып түзсәм түзәм, Читкә чәчмим зарларымны.* Р.Батталов. **Читкә чыгару** Берәр серне, яшерен мәгълүматны ялгыш сөйләү, ычкындыру. *И падишаһ, синең хөкемеңә лаек вә тиешледер ки, вәзирләрең сүзен читкә чыгармыйсың.* К.Насыйри. **Читкә чыгу** 1) Төп, үзәк нәрсәдән тайпылу; игътибарны башка нәрсәгә юнәлтү. *Я, ярар, төп темага керик әле, мин монда фәнни хезмәт язмыйм, андый гына читкә чыгып керүләр булыр инде ул.* М.Мәһдиев; 2) Билгеле бер кысаларны сакламау; нәрсәдәндер азат булу. *Ләкин хатның бер сүзе дә мин әйткән сүзләрдән читкә чыкмаска тиеш, юкса анаңа авырлык килүе бар.* А.Алиш; *Әсәрләрнең художество эшләнеше, әдәби алымнар кулланылуы ягыннан Гафур үз заманының әдәбияты йогынтысыннан читкә чыга алмаган.* Г.Нигъмәти; 3) Ят кешеләргә мәгълүм булу, хәбәре таралу. *Хәбәр читкә чыгарга өлгерде*

**ЧИТКӘРЕ** *рәв. диал.* Читкә, бер якка

**ЧИТКӘ́ ЧЫГАРУ** *и. икът.* Берәр төрле товарны, хезмәт күрсәтү, интеллектуаль хезмәтне чит илгә озату, сату; экспорт. *Гомумән, форумда товарны читкә чыгару проблемасы ныклап тикшереләчәк.* Татар заманы

**ЧИТКЕ** *с. диал.* Читтәге, читтә булган. *Айбала үзенең уйларга өйрәнмәгән башы белән бу эшнең очына чыга алмады, иярле Байчобар бәйләвендә тибеп торган читке ак тирмәгә кайтып китте.* Г.Ибраһимов

**ЧИТЛӘП** *рәв.* 1) Әйләнеч юллар белән, әйләнеп; кермичә, кагылмыйча. *Әй, мәхәббәт, алдакчы... Ник мине читләп йөрисең ---.* Н.Сафина. *Зинһар, кошчык, бу урманны читләп үт.* Ш.Гаделша

2) *к.* **читләтеп** (*2 мәгъ.*). *Күл читләп, каек көймәдә Гыйльми йөзеп килә иде.* Ә.Моталлапов. --- *Атлагыз читләп кенә, Олы юлга кермәгез, Карамыйча йөрмәгез!* Э.Шәрифуллина. *Урамга чыккачтын да башта өй каршындагы койма читләп атлады Рафаэль.* Р.Мөхәммәдиев

3) Чит-читеннән эләктереп

4) Почмаклап, почмаклар ясап. *Өч читләп төргән бөтине кулыма китереп тә тоттырды.* С.Җәлал

5) *куч. к.* **читләтеп** (3 *мәгъ.*). *Читләп булса да җепләрен тартып карарга кирәк, аннан соң гына берәр сүз әйтермен, дип уйлады.* Г.Ибраһимов

◊ **Читләп узу** *к.* **читләтеп узу**. *Еллар аша барган чакта очратсаң Югалтулар чәрдәкләгән язмышларны – Читләп узма – (мин дә – яра) Табиб бул син ---.* Г.Морат. *Шатлыкларым булды, җиңүләрем, Кайгылар да читләп узмады.* И.Гыйләҗев. **Читләп үтү** *к.* **читләтеп узу**. *Эх бәхеткәй, бәхеткәй, Читләп үтмә бүген син!* А.Гадел

**ЧИТЛӘТЕП** *рәв.* 1) Нинди дә булса урынга кермичә, кагылмыйча; якын килмичә, аны урап узып. *Сөмбелә керсен, сез дә кайткан-киткән чакларда читләтеп үтмәгез, керегез!* А.Гыйләҗев. *Партизаннардан өрәктән курыккандай шүрләп килгән немецлар моңа кадәр тау-ташлы урыннарны, урманболыннарны читләтеп үтү ягын карыйлар иде.* А.Фәләх

2) *сөйл.* Чит-читләре буенча, чит-читләренә урнаштырып, нәрсәдер чите буенча. --- *сандалиларын ике якка ыргытып, маймычлары өерелеп йөзгән су читләтеп йөгерде...* К.Кәримов. *Иң мөһиме эшләнде, ләкин әле аны казып тазартасы, читләтеп таш тезәсе бар иде.* З.Мурсиев

3) *куч.* Кинаяләп, ишарә белән; турыдан-туры түгел. *Монысы инде Шәйхинең минем авторитетка читләтеп суктыруы, мәкер белән эш йөртә башлавы иде.* В.Нуруллин. *Бу турыда шулай ук Фирдәвес Гарипова, Д.Рамазанова, Марсель Әхмәтҗанов, Һади Атласи һәм башка авторлар читләтеп булса да язалар һәм язганнар.* И.Хуҗин

◊ **Читләтеп узу** 1) Берәр тема, мәсьәлә һ.б.ш.га кагылмау, тукталмау, аны кузгатмау. *Хастаханә тормышын каләм ияләре ничектер читләтеп узалар, һәм бу аңлашыла да.* Д.Гыйсметдин. *Мөсәгыйть Хәбибуллин да бу теманы читләтеп узмаган.* И.Нәбиуллина; 2) Шатлык, кайгы һ.б.ш. нәрсәләрнең булмый калуы. *Бүгенгә бәла читләтеп узсын!* А.Гыйләҗев. *Бу хисләр кайсы адәм баласын читләтеп үтә алыр икән?* Б.Рәхимова. **Читләтеп үтү** *к.* **читләтеп узу**. *Бәхетегезне читләтеп үтмәгез.* Г.Әпсәләмов

**ЧИТЛӘТҮ** *ф.* 1) Читкә этү, аеру; ераклаштыру. *Мәхмүтсафа, димчеләргә кулы белән ишарәләп, сандыктан читләтә дә хуҗа булып ябып та куя.* А.Гадел

2) Эштән, вазифадан бушату. *Аз гына мөмкинлек күренү белән, театр директоры Алханов артистка Салиәскарованы эштән читләтү турында 104 нче фәрманга кул куя.* М.Гайнетдинов

3) Якын итмәү; санга сукмау, кимсетеп карау. *Ләкин ул халыкны белми, үзенең сыйнфый хәле, социаль тәрбиясе белән аннан аерылган, хәтта халык тормышына читләтеп карый.* М.Хәсәнов. *Милләттәше көндәш булыр дип, аны кимсетергә, читләтергә һәм аңарга яла ягарга тырыша.* Р.Вәлиев

4) Игътибарга алмау. *Шунлыктан гаиләдә дә кайвакыт бу мәсьәләләрне читләтеп булмый.* Р.Вәлиев

**Читләтә башлау** Читләтергә керешү. *Кызганычка каршы, соңгы елларда язучыларыбыз бу жанрны читләтә башлады.* Л.Җәләй

**Читләтә төшү** Бераз читләтү. *Юныс тәкъдимен, үзенең ни уйлаганлыгын чыгарып селкергә ашыкмады, читләтә төште.* Р.Мөхәммәдиев

**ЧИТЛӘ́Ү** *ф.* 1) Берәр нәрсәнең читчитен тоту, каю. *Өстендә гәүдәсенә ятышлы итеп тегелгән, заманы өчен ятрак булган ак батист күлмәк, аягында капрон оеклар, зәңгәр белән читләгән ак тапочка... нәкъ күбәләк инде.* Шәһри Казан // Каймалау, кайма тоту. *Анда төрле кул эшләренә өйрәнәбез: бисердан бәхет агачлары, төсле тасмалардан кабартып ясалган чәчәкләр беркетеп, кечкенә мендәрләр тегәбез, салфеткалар читлибез, чигәбез, бәйлибез.* Туганайлар

2) Чит-читләрен буйдан-буйга ырмаулау, ырмау алу, җек алу. *Дөрес, Вәрис: «Син болында чакта, такта алдым, читләдем, шомарттым», – дип, шатлыгын уртаклашкан иде.* Р.Газиз

3) Берәр нәрсә белән чит-читләрен билгеләү, аеру. *Китапханә хадимәсе, өенә кайтырга талпынып, бер – аның иелгән киң җилкәсенә, бер дивардагы шакмаклы кара рам читләгән сәгатьнең өнсез-тавышсыз шуышкан чукмар телләренә карап-карап куядыр.* А.Гыйләҗев. *Иң беренче – рам белән читләп эшләнгән 30×35 см зурлыгындагы фанер кара такта кирәк.* Фокус серләре

4) Якын килмәү, читтән генә үтү, урап узу; тимәү. *Ярый әле, җаным, исән калдың. Ярый әле пуля читләде, Ярый әле, сине бездән алып, Тормыш безне ятим итмәде.* Ш.Маннур. *Тик шулай да үзем читләп йөрим, Качып йөрим синнән.* Р.Вәлиев

5) Аеру, аралашудан мәхрүм итү. *Син чакырып керткән чит-ят күзләр Үзеңне дә миннән читләде.* Ф.Дәүләтгәрәева. *Бу, әлбәттә, күпләрне алардан читләде.* Безнең гәҗит

6) *куч.* Үз итмәү, якын итеп санамау, санга сукмау, читләштерү. *Сарыкка имәргә кушылган кәҗә бәкәедәй, гел читләде.* Ф.Яруллин. *Ахры, мине тормыш читләп уза...* Р.Гаташ. *Яшәүнең кайсыдыр ягы Гел сине читли кебек.* Л.Лерон

**Читли төшү** Бераз читләү. *Хәзер инде миңа болай... әллә ничек, Читли төшебрәк карыйлар...* Һ.Такташ

**Читләп чыгу** Башыннан ахырына кадәр читләү. *Буяулар кулга йокмый башлагач, алтын төстәге контур белән төртке артыннан төртке төртеп, һәр бизәкне читләп чыгабыз.* Сөембикә

**ЧИТЛӘШКӘНЛЕК** *и.* 1) Нәрсәдәндер читләшкән булу, аерымланганлык, битарафлык. *Кешеләр үз җаваплылыкларын тойдылар, апатиядән һәм читләшкәнлектән арына баралар.* Ә.Рәшитов. *Бу көн тормышыннан абсолют читләшкәнлек күрсәтү аның табигатенә, характерына чит нәрсә ич!* М.Гайнетдин

2) Үз дөньясына чуму; ятсыну. *Ләкин бу юлы кызның йөзендә читләшкәнлек төсмерләре сизелә.* Х.Камалов. *Шул сәбәптән шагыйрь иҗатында суфичылык һәм читләшкәнлек мотивлары барлыкка килә.* Ч.Зарипова

**ЧИТЛӘШТЕРҮ** *ф.* 1) Кемне дә булса дуслык, якынлык мөнәсәбәтеннән мәхрүм итү, аның белән араны өзү, аралашмау. *Ул – бөтенләй башка кеше, башка шартларга куелган, җәмгыять читләштергән элемент.* А.Гыйләҗев // Берәүләрнең дуслыгын бетерү, араларын бозу. *Менә нигә илтә тарихны берьяклы итеп мәктәп балаларын укыту – бер илдә яшәгән халыкларны читләштерә икән ич!..* М.Хәбибуллин

2) Эштән, вазифадан азат итү. *Бу акылсызлыгыгыз өчен мин сезне бүген үк эштән читләштерәм һәм арестовать итәм.* Г.Әпсәләмов. *Моның өчен, ничек сәер тоелмасын, минем юлымда киртә булып яткан Рәфисне баш зоотехниклыктан да, партбюро әгъзалыгыннан да читләштерергә кирәк.* А.Вергазов

3) Берәр нәрсәне куллану, аңа мөрәҗәгать итү гадәтен бетерү. *Компьютер җиһазлары, Интернет системасы инде бик күп яшьләребезне китаптан читләштерде.* Р.Вәлиев

4) Үз күрмәү, якын итмәү. *Күзләрендә үтенеч иде этнең – кешеләр, сез минем хуҗамны кимсетмәгез, аның акылы сайрактыр, әмма ул тиле түгел, читләштермәгез аны үзегездән, ялгызлыктан күп интеккән ул ---.* М.Хуҗин. *Хәйлә иде бу, Халидә аны үзеннән читләштерә иде.* Н.Гыйматдинова

5) Берәүнең милкеннән тартып алып, икенче кешегә бирү, аның милке итеп санау. *Карганыкы да үзләренә кирәк булып калачак, бернинди закон белән дә җирләрне читләштереп булмаячак.* М.Миначев

**Читләштерә бару** Торган саен күбрәк читләштерү. *Аның һәр сүзе, һәр хәрәкәте мине элекке беркатлы, сабый җанлы Шәһиттән аера, читләштерә барды.* Ф.Садриев

**Читләштерә башлау** Читләштерергә тотыну. *Син миңа суындың кебек, мине читләштерә башладың кебек.* Н.Фәттах. *Мондый ачыш аны рәсем белән җенләнүдән дә, ярыйсы гына бирелә башлаган укуыннан да читләштерә башлый.* К.Җәмит

**Читләштереп бетерү** Бик нык читләштерү. *Аерым бүлмә, ят һөнәр, берсеннән-берсе тәкәбберрәк күренгән хезмәттәшләр – барысы да Кәримәне дөньядан читләштереп бетергәннәр иде инде.* К.Тимбикова. *Кешеләрне Сафыйның комсызлыгы, саранлыгы читләштереп бетерде.* Г.Гыйльманов

**Читләштереп куе** Кинәт яки алдан ук читләштерү. *Ләкин бу сүзе дә юкка түгел: шушы бер җөмләсе белән ул, җиңел генә итеп, Дәүләтшинны операциядән бөтенләй читләштереп тә куйды.* М.Маликова

**Читләштереп тору** Вакытлыча читләштерү. *Дөрес, ул олуг кенәз фатихасы һәм ярдәме белән яу чабып, агасын тәхеттән читләштереп торган иде торуын.* М.Әмирханов. *Шушындый хәл аркасында, заманында Мәрҗани хәзрәтне дә имамлыгыннан читләштереп торганнар.* А.Тимергалин

**ЧИТЛӘШҮ** *ф.* 1) Тайпылу, бер якка китү, бер читкәрәк китү. *Эше белән мәшгуль булып, тәрәзәдән читләшә.* А.Гадел. *Урта бер җирдә хәрәкәтсез басып торган алмачуар ат арык янбашларын сәер генә сикертеп читләште.* М.Маликова

2) Якынлык, дуслык мөнәсәбәтләре бетү, аралашмый башлау. *Ата – улдан, бала атадан читләшсен инде...* Р.Вәлиев. *Соңыннан керми үк башлады безгә, читләште.* А.Гыйләҗев

3) Игътибар, фикер һ.б.ш.ны башка нәрсәгә юнәлтү. *– Балалар, без бүген программадан бераз читләшәбез, – диде.* Н.Акмал // Эштәге, яшәүдәге төп юнәлештән тайпылу, башкача эш итү; оныту. *Ул надан хатыны һәм кара фикерле кайнанасы йогынтысында тормыш идеалларыннан читләшә.* А.Әхмәдуллин. *Без гомер буе ясалган ясалма нәрсәләр ярдәмендә реальлектән читләшеп яшибез.* З.Хәким

4) Тыелу, нидер эшләмәү; берәр мәсьәләгә кагылмау, сүз кузгатмау. *Сәясәт хакындагы сөйләшүләрдән читләшә.* Р.Мөхәммәдиев. *Әти-әнисе бу хакта сөйләшүдән гел читләштеләр.* М.Кәбиров

5) Кулланмау, файдаланудан туктау; бизү. *Ә тамашачыларыбыз операга сусый... дип әйтер идем – ышанмассыз, чөнки халкыбыз күптән инде бу жанрдан читләште, суынды.* И.Юзеев. *Дөрес, байтагы туган телендәге матбугаттан читләшкән инде.* Т.Әйди

6) Кушылмау, катнашмау, керешмәү, качу. *Бу мәшәкатьле эштән бөтенләй читләш, сиңа башка эш беткәнмени, дип «киңәш» бирүчеләр дә табылды.* Г.Әпсәләмов. *Ә бит мобилизациядән сәбәпсез читләшкән кеше дезертир булып санала, ә сугыш чорында дезертирны, үзегез беләсез...* Ф.Сафин

7) *күч.* Дөнья белән бәйләнешне өзү, башка нәрсәләр турында уйлау. *Кыз тагын да артка таба карап, читләшкәндәй утырды.* Ф.Яхин. *Бүген ул үзен бөтен дөньядан читләшкән, канаты сынган ялгыз чәүкә итеп тойды.* Д.Каюмова

**Читләшә бару** Торган саен, акрынлап читләшү. *Читтә ялгыз яшәгән кеше андый рухи җаваплылыктан, үзен тикшерә, дөресли торудан әкренләп читләшә бара.* Ш.Галиев. *Хәлим белән Майя хакында уйлаган саен Нәфисә Хәлимнән читләшә бара.* Г.Гыйльманов

**Читләшә башлау** Читләшү билгеләре күренү. *Мансур нигәдер аңардан читләшә башлады, Гөлшәһидә Казанка буена чакырса, әллә нинди сәбәпләр табып, анда бармаска тырышты.* Г.Әпсәләмов. *Өйдән читләшә башладың...* А.Гыйләҗев

**Читләшә бирү** Бернигә карамыйча һаман читләшү. *– Мин – комсомолка, советская! – дип кенә җавап биреп, бәхәстән читләшә бирде.* Ф.Яхин

**Читләшә төшү** Бераз читләшү. *Алар бер-берен бик сагынган булсалар да, бераз читләшә дә төшкәннәр иде.* Р.Мөхәммәдиев. *Соңга таба, Зарема балага узгач, Габор читләшә төште, бүтән яшь хатыннар тирәсендә чуала башлады.* И.Диндаров

**Читләшеп алу** Берара читләшү. *Шулай да үзебез сайлаган шушы принциптан бер генә урында читләшеп алуны укучы гафу итәр әле.* М.Хәсәнов. *Сара әбинең аларны сагынганын барысы да беләләр, хәтта ул, берничә тапкыр уйланып китеп, алардан читләшеп алгач, ахирәт дуслары, нигә үзеңне шулай бетерәсең икән дип, сүккәләп тә куя торган булдылар.* Ф.Яхин

**Читләшеп бару** Акрынлап читләшү. *Аңлыйм, әмма бөтенләй читләшеп бара түгелме?* Ф.Яхин. *Диннән читләшеп барасыз.* З.Мурсиев

**Читләшеп бетү** Бөтенләй читләшү. *Бөтенләй читләшеп беттек бит әле бу арада.* Н.Фәттах. *Хатын белән читләшеп беттек.* Т.Галиуллин

**Читләшеп йөрү** Озак вакытлар яки соңгы арада читләшү. *Шуңаргамы, авыл балалары белән дуслашып китә алмыйча, озак кына читләшеп йөрде.* Ф.Яруллин. *– Мәңгегә! – дидек без. Бүген ник үзебез Читләшеп йөрибез?!* Р.Гаташ

**Читләшеп кую** Кинәт читләшү. *Менә ничек бит ул: күрмәгәндә, без бер-беребезгә бик якын идек, күзләр ачылгач, кинәт читләштек тә куйдык.* М.Маликова

**Читләшеп тору** Вакытлыча, беразга читләшү. *Вакытлыча акыл хезмәтеннән читләшеп торыгыз.* З.Мәхмүди. *Әмма Габдрахманга бәйсез сәбәпләр күпмедер вакытка актив иҗаттан читләшеп торырга мәҗбүр итә.* Г.Гайнуллина

**ЧИТЛЕК** *и.* 1) Кошлар яки вак җанварларны асрау өчен, яклары һәм өсте металлдан яки агачтан рәшәткәләп ясалган кечкенә корылма; *русчасы:* **клетка**. *Ә попугай гел өйдә, гел читлек эчендә.* А.Хәсәнов // Кыргый хайваннарны зоопарк, цирк һ.б.ш.да асрау өчен, яклары һәм өсте тимерчыбыктан рәшәткәләп эшләнгән корылма; *русчасы:* **вольер**. *Арматурщиклар бармак юанлыгы тимерчыбыклардан, ерткычларга читлекләр әзерләгәндәй, тимербетон өчен челтәрле рәшәткәләр үрәләр.* А.Алиш. *Халык бик күп, читлеккә якын да барырлык түгел.* Г.Әпсәләмов

2) Корт анасын ябу өчен металл челтәрдән ясалган тартмачык. *Андагы --- коры умарталар, читлек, күзлек, тубал кебек нәрсәләргә без ияләшеп беткән идек.* М.Гафури. *Бу читлекнең бөтен дүрт стенасы тишекле тимерчыбык челтәрдән ясала.* Умартачылык

3) *күч.* Төрмә, төрмә камерасы. *Егетнең дә шактый гомере тимер читлек эчендә югалды...* А.Әхмәтгалиева. *Аннары инде, белгәнегезчә, егерме ел читлектә утырдым.* А.Нәҗми

4) *күч.* Ирекне чикләп торган нәрсә. *Килде форсат кысан читлекләрне итәргә тар-мар, Килде, иркен сулыш алып, вакытыбыз канат кагар.* Г.Тукай. *Җан кеше тәне читлегендәге кош кебек, һәм аның бу читлектә (яки савытта) күпме торачагын берәү дә белми.* А.Тимергалин

◊ **Читлектәге бүре кебек (сыман, төсле, шикелле)** *к.* **читлектәге җанвар кебек (сыман, төсле, шикелле)** *Нашир исә, читлектәге бүре төсле, Идән буе арлы-бирле атлап йөри.* Г.Тукай. *Ләкин аның күзләренә йокы кермәде, ул, читлектәге бүре кебек, камераның түреннән ишегенә, ишегеннән түренә үзен туктата алмый һаман кызу-кызу*

*йөрүендә булды.* Г.Ибраһимов. **Читлектәге җанвар кебек (сыман, төсле, шикелле)** Ярсып, котырынып, тузынып. *Баласын кочаклады да, урыныннан атылып торды да, тыелудан тәмам тәкатьсез калып, читлектәге җанвар сыман, әрле-бирле идән буйлап йөренергә тотынды.* Н.Фәттах. *Шуңа күрә шәмәхә төстәге, утыртма якалы, уртадан бер рәт сәдәпле, каешсыз китель һәм диагональ галифе чалбар кигән Әблиев, читлектәге җанвар кебек ярсып, ишекле-түрле йөренде.* Р.Кәрами. **Читлектәге кош кебек (сыман, төсле, шикелле)** 1) Моңаеп, күңелсезләнеп. *Операция яхшы үтүгә карамастан, малай һаман читлектәге кош шикелле моңаеп ята.* Г.Әпсәләмов; 2) Тарсынып. *Күңел ашкына, рухыбыз, читлектәге кош кеби, ялгызлыкка, азатлыкка омтыла.* Г.Ибраһимов. **Читлектәге тиен кебек (сыман, төсле, шикелле)** Бик җитез хәрәкәтләнеп; борсаланып. *Дәрес вакытында нинди боргаланусыргалану ди ул? Читлектәге тиен кебек утырасыз.* В.Нуриев

**ЧИТНӘ́Ү** *ф. диал. к.* **зыянлау**. *Аларның сыеры читнәгән*

**ЧИТСЕНҮ** *ф.* 1) Ятсыну, чит кешедән оялу, уңайсызлану, читенсенү. *Тик без бер-беребездән тартынабыз, читсенәбез.* Ә.Гаффар

2) Читләтү, читләтеп үтү. *Гүяки язучы аңлы рәвештә детальләрне читсенә.* Ф.Хатипов

3) Чит итеп карау, чит итеп хис итү, ят санау, үз итмәү. *Авырулар әле булса аңа читсенеп, ышанып бетмичә карыйлар.* Г.Әпсәләмов. *Бу каләмдәшләребезгә читсенеп, үгисетеп карау әдәбиятыбызны тарайту булыр иде.* Р.Фәйзуллин

**Читсенә бару** Торган саен күбрәк читсенү. *Икенчедән, һәркем үз шәхси дөньясына, гаилә кабыгына кереп бикләнергә мәҗбүр булган, бер-беребездән еракланша, читсенә барган четерекле заманда, аена бер-ике булса да, төрле буын фәнни юнәлеш вәкилләре --- басылып чыккан китаплары белән мактанышу, бүләк итешү мөмкинлеген алалар.* Т.Галиуллин

**Читсенә башлау** Читсенергә тотыну. *18 яшендә ул үзенең 80 кг булуыннан читсенә башлый, спорт белән шөгыльләнә, 8 айда 20 кг га ябыга.* Ялкын

**Читсенеп йөрү** Озак вакытлар яки соңгы арада читсенү. *Җитәрлек каңгырып, читсенеп йөрдек, һай, адәм күңеле түзсә дә түзә икән!* А.Гыйләҗев

**Читсенеп тору** Әле читсенү. *Аңарчы үзләрен җыелышның үгирәк баласы кебек, бераз читсенеп торган татарлар төрле яктан кычкыра башладылар ---.* Г.Ибраһимов

**ЧИТТӘ́** *рәв.* Берәр нәрсәдән ераграк; аерым рәвештә, башкалардан аерылып. *Улым, ханнар, солтаннардан читтә йөр!* А.Гадел

◊ **Читтә калу** 1) Берәр эштә катнашмау. *Мин дә читтә кала алмадым, шул бәргәләшнең эченә кереп, уңга-сулга яңаклый башладым.* Г.Ибраһимов. *Без дә бу килешүдән читтә калырга тиеш түгел.* А.Тимергалин; 2) Берәр сыйфатка, үзенчәлеккә ия булмау. *--- европоцентризм теориясе башка илләрне һәм халыкларны тарихның дөрес үсү юлыннан читтә калганнар дип күрсәтергә тырыша.* Ш.Сафин. *Чаллы да мәдәнияттән читтә калмый.* Мәйдан; 3) Игътибар үзәгендә булмау; исәпкә алынмау. *Адәмнәр генә түгел, хайваннар да әдип каләменең характеристикасыннан читтә калмаганнар.* Казан утлары. *Хәлбуки биредә кайбер катлаулы мәсьәләләр читтә кала әле.* К.Гыйззәтов. **Читтә торсын** «Башка нәрсәләрне уздыра», «күпкә артык», «башкача кирәк түгел» мәгънәсендә. *Бу караш төбәлсә, рентгенның читтә торсын.* Т.Гарипова. *Безнең бакчалар – во! Дачаң читтә торсын!* Н.Гаетбай. **Читтә тору** *к.* **читтә калу**. *Сәгыйть Сабитов инде ул Кәрим бай кебек тар карашлы, культурадан читтә торган тупас кеше түгел.* М.Гали. *Мин гомерем буе уеннан читтә тордым.* Г.Әпсәләмов

**ЧИТТӘ́Н** *рәв.* 1) Кырыйдан, ерактан, бер әйбердәнерактарак урыннан, бер яктан. *Буадан берәр чакрым читтән үтә торган олы юлга чыгып, канау буена чирәмгә утырдылар.* А.Тимергалин

2) *биол.* Икенче үсемлек серкәсе белән, бер чәчәктән икенче чәчәкнең җимешлегенә серкә күчеп. *Ләкин күпчелек ябыгорлыклылар читтән серкәләнә – бер үсемлекнең серкәләрен икенче үсемлеккә җил, бөҗәкләр, кошлар күчерә.* Биология

3) Чит кешедән, башкалар аша (ишетү, белү). *Булатов та бу сүзләрне читтән генә ишетте, ләкин берни эшләргә дә мөмкин түгел иде.* А.Алиш

◊ **Читтән караганда** Нәрсәне дә булса махсус тикшермәгәндә; якыннан белмичә эш иткәндә, фикер йөрткәндә. *Читтән караганда Җәмилнең тормышы ал да гөл иде.* Н.Әхмәдиев. *Без давылның үзе түгел, Ком бураннары гына. Болай читтән караганда Сүнгәндәй күренәбез ---.* И.Юзеев. **Читтән карап тору** Турыдан-туры шөгыльләнмәү, эштә катнашмау. *Бәлки яратылышыннан бирле һәрнәрсәгә читтән карап торырга өйрәнгән авыл халкы да революция тәгәрмәченә эләкте.* Г.Ибраһимов. *Читтән карап торып кына йөзәргә өйрәнмиләр.* В.Имамов

**ЧИТТӘ́Н КЕРТҮ** *и. икът.* Чит илдән товар, хезмәт күрсәтү, интелектуаль хезмәт кертү, сатып алу; импорт. *Татарстан фермерлары үзләре җитештерә торган товарны читтән кертү 40 процентка диярлек арткан.* Шәһри Казан

**ЧИ́Т-ЧАТ** *и.* 1) Төрле урыннар, читтәрәк, кырыйдарак урыннар. *Ызан башларында, чит-чатларда алабутага тикле күренми хәзер.* Э.Касыймов

2) *к.* **чит-чите**. *Алар бигрәк ак, курчак күлмәге кебек, чит-чатлары челтәр белән каеп эшләнгәннәр.* Г.Гыйльманов

**ЧИ́Т-ЧИТЕ** *и. тарт. форм.* Нәрсәнең дә булса әйләнә чите, ян яклары. *Башында чит-читләре чуклы ефәк калфак, муенында көмеш кыңгырау.* А.Хәсәнов. *Имәнне үткәч, чит-читенә шомырт агачлары үскән кечкенә генә, түгәрәк кенә аланга чыгабыз.* А.Гыйләҗев

**ЧИ́Т-ЧИТКӘ** *рәв.* Төрле якка, төрле янга. *Карчык чит-читкә карап, өстәл өстендәге шикәр савытыннан берничә кисәк шикәрне кесәсенә сала ---.* Г.Исхакый. *Көшелләр өстенә капланган җәймәләрне дер селкетте, чит-читкә өелгән кибәкләрне тузгытты җил.* Р.Мөхәммәдиев

**ЧИ́Т-ЧОТ** *җый. и.* 1) Төрле чит җирләр. *Әгәр без шулай кыланмасак, читкә-чотка сатып җибәргән материалларны, цементны, башкасын ничек списать итәр идек?* А.Гыйләҗев

2) Читтәге, кырыйдагырак юллар, урыннар. *[Закир:] Читтән-чоттан гына йөрсәк тә, танышлар.* А.Гыйләҗев

3) **читтән-чоттан** *куч.* Туры әйтмичә, кыеклатып. *Бу кинәтлек Наиләне куркытты: Наилә, читтән-чоттан сораулар биреп, аның җебен тартып карады.* А.Гыйләҗев

**ЧИ́Т-ЯТ** *с.* **1.** Бөтенләй чит, ят булган. *Фомич Азатны олы юлдан читтәрәк, урыны-урыны белән яшел чирәм дә борын төрткән гади авыл юлларыннан барырга өйрәтә, шуңа күрә чит-ят кеше, хәрби машиналар очратмыйлар.*

А.Тимергалин. *Бүген мин бөтенләй читят, үзгә дөньяга эләктем.* А.Мансуров

**2.** *и. мәгъ.* Бөтенләй чит, ят кеше. *Кем ул чит-ятларның күзен ачып, дикъкатьләрен безгә юнәлтә?* А.Тимергалин. *Матурлыгыңа чит-ятларның сокланып күз салуы, синең бүтәннәргә елмаеп каравың мине чыгырымнан чыгара.* А.Әхмәтгалиева

**ЧИЧӘ** I *и. диал. к.* **тәти**

**ЧИЧӘ** II *и. тар.* Берничә хатынлы гаиләдә баланың үз анасы. – *Әкәм белән чичәмә зур үпкәм бар: мине бу һөнәргә өйрәтми калдырганнар, – диде.* Г.Ибраһимов

**ЧИЧӘН** *и. тар.* **1.** Борынгы халык шагыйре; шагыйрь-импровизатор, нәфис сүз остасы. *Чичәннәр, мәзәкче, әкиятчеләр, тапкыр сүз, матур хикәяләр сөйләп, шаһның күңелен хушландырдылар, тамашачыларны көлдерделәр.* К.Насыйри. *Иген кырларына бәрәкәт кунмый, Басып китсә сарут, билчән генә; Күп сүзнең дә игелеге булмый, – Син дә чичән түгел, телчән генә.* Н.Арсланов

**2.** *с. мәгъ.* Импровизатор сәләтенә ия булган. *Чичән җырчыларга сокланганга Ул бай телнең оттым серен мин.* Н.Арсланов. *Бу тамаша чичән шагыйрьләрнең ярышыннан ким түгел.* Ф.Абдуллин

**ЧИЧӘНЛЕК** *и.* Үз әсәрен үзе башкарып торган вакытта иҗат итү, импровизаторлык сәләте. *Импровизаторлык-чичәнлек традицияләре дә онытылып бетмәгән.* Р.Фәйзуллин. *Шул сәфәрдән соң, Илдар абыйның чичәнлегенә кайбер мисаллар язып куйганмын.* Р.Миңнуллин

**ЧИЧӘРҮ** *ф. диал.* Тапкыр, үткен сүзләр әйтү, җорлану. *Курай уйнап чичәрде шунда берсе.* Ф.Бурнаш

**ЧИЧИ** *и. диал. к.* **чичә** I. *Суык көннең суыклыгыннан куркудан юашланган кеби күренә торган кояшның нуры аның чичиендә уйный башлады.* Г.Ибраһимов

**ЧИ́-ЧИ** *иярт.* Тычканнарның, кош балаларының һ.б.ш. хайваннарның чиелдавын белдерә

**ЧИЧИКАЙ** *и. диал.* 1) Пыяла, фарфордан эшләнгән савыт

2) Шундый савытның ватылган кисәге. *Чичикайларны – аллы-гөлле чынаяк ватыкларын – күмгән җирләреннән казып чыгарырга бик теләсә дә, Мохтар балыкка барырга риза булды.* Г.Мөхәммәдова. *Әгәр дә метеорит дигәнең юк кына бер чуерташ кисәге – биш тиенлек чичикай кебек нәрсә булып чыкса?..* Д.Гыйсметдин

**ЧИ́-ЧИ КИЛҮ** *ф.* Чи-чи сыман тавыш чыгару. *Кошчыклар --- барысы да башларын шул якка таба борып, зур авызларын ачып, чи-чи килделәр.* Г.Гобәй

**ЧИЧИН** *диал.* 1) Чыбыктан үреп ясалган чана әрҗәсе. *Чичин үрү*

2) Әрҗәсе чыбыктан үрелгән чана. *Чичингә утыру*

**ЧИЧҮНЧӘ** *и. сөйл. к.* **чесуча**. *Аксыл чичүнчә костюмлы, кырма сакаллы татар карты да төргәк эченә үрелеп карады.* Г.Ахунов

**ЧИШЕК** *с. сөйл.* Чишелгән, төймәләнмәгән; җилбәгәй, җилбәгәй җибәрелгән (кием-салым тур.). *Өстендә сары күлмәк, изүләре чишек, куллары озын, әллә тагын тезләреннән үк узып торалар.* Г.Бәширов

**ЧИШЕЛЕШ** *и.* 1) Нинди дә булса мәсьәлә, эшнең хәл ителү юлы, шуның ахыры, нәтиҗәсе. *Әмма бар икән ич хәл ителмәстәй тоелган мәсьәләләрнең чишелеше!* М.Хуҗин. – *Башкача чишелеш юк, хөрмәтлем, – диде дә, кинәттән генә нәрсәнедер исенә төшергәндәй сискәнеп, маңгаен уа-уа, өске катка таба атлады.* А.Хәсәнов

2) *мат.* Математик мәсьәләне чишү ысулы, принцибы // Мәсьәләне чишкәннән соң килеп чыккан нәтиҗә, җавап. *Кемдер ручка башын кабып уйга калган, кемдер мәсьәлә чишелешен, ашыга-ашыга, дәфтәренә төшерә.* Г.Әдһәмова. *Рәзифә апа математикадан бирелгән өй эшләрен күчертә ---: математиканы су урынына эчкән кыз моның өчен мәктәпкә махсус гел алдан килә, кыңгырауга чаклы аның дәфтәрендәге катлаулы мәсьәләләрнең чишелеше Мөхәммәтнең дәфтәрендә урын алганын түземлек белән көтә.* З.Хөсния́р

3) *әд.* Әдәби әсәр сюжетының үсешен тәмамлый торган эпизод, вакыйга. *Пьесаның һәм спектакльнең чишелеше оригиналь.* А.Әхмәдуллин. *Тылсымлы әкиятләрнең композициясенә башлам, эпик өлеш (төенләнеш, вакыйгалар үсеше, кульминацион нокта, чишелеш) һәм бетем хас.* Л.Җамалетдинов

**ЧИШЕЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **чишү**. *Шунысын да искәртик: әлегә бу шагыйрьгә бәйле күп кенә мәсьәләләрнең фән тарафыннан чишеләсе бар.* Ф.Яхин

2) Бәйләнгән, төенләнгән бау, шнур, җеп һ.б.ш. нәрсәләр сүтелеп китү. *Чиләкне юньләп бәйләмәгәнмен икән, төен чишелде, чиләк быгыр-быгыр суга батты...* А.Гыйләҗев. *Ат хәтта бәйләнмәгән дә, тезгене чишелгән, ул, башын төрле якка йөртә-йөртә, кар өстеннән азык эзләгәндәй итә ---.* З.Хөснияр

3) Берәр уралган, төрелгән әйбер сүтелеп, ачылып китү. *Төенчек чишелеп, яулык бушатылды.* В.Сәфәров

4) Кием-салым төймәсеннән, каптырмасыннан ычкындырылу; ычкынып ачылу. *Сукно пальто чишелгән, һәм сарык йоныннан бәйләнгән ак шарф арасыннан таза кызыл күкрәк уемы күренеп тора.* М.Мәһдиев. *Тун изүе ярым чишелеп, кызгылт шарфы тышка салынып торган килеш карга ятып ауный-ауный үкерде...* А.Вергазов

5) *күч.* Ачыклану; хәл ителү. *Күрәсез, бу – тормыш үзе китереп куйган зур проблема, һәм ул чишелергә тиеш...* Г.Гомәр. *Мәсьәлә чишелмәде, әмма тиешле бер юнәлеш, ачыклык алды.* А.Гыйләҗев

6) *күч.* Берәр яшерен, сер булган нәрсәне ачыктан-ачык сөйләп бирү; эчтәгесен тулысынча сөйләү, әйтергә базмаган нәрсәләрне әйтеп ташлау. *Шунлыктан ахирәтлек белән генә чишелә алмаслык серләрне дә бу тугрыда яшерергә лөзүм тапмый.* Г.Ибраһимов. *Гөлфинур моңарчы үзен йөгәнләп, тыелып кына сөйләшә иде, кинәт ул чишелеп, туарылып китте.* А.Вергазов

**Чишелә бару** Торган саен күбрәк чишелү. *Берәм-берәм юлда чишелә барган синең серләр, аның шикләре.* К.Сибгатуллин

**Чишелә башлау** Чишелергә тотыну. *Кәримәнең күңелендә тулган, төенләнеп торган хиссиятләр чишелә башлады.* Г.Исхакый. *Шөкер, соңгы елларда авылыбызда күп кенә борчулы мәсьәләләр чишелә башлаган: балалар бакчасын төзеп маташалар, юлларга асфальт салына, мәктәп яшәп килә.* Д.Гыйсметдин

**Чишелә килү** Әлегә кадәр билгеле бер эзлеклелектә чишелү. *Рәхмәт аның егерме биш гасыр чишелми килгән табышмагына!* М.Галиев. *Әлбәттә, аларның бер ишеләре чишелә килде, икенчеләре туып торды.* Өмет

**Чишелә тору** Әледән-әле, туктаусыз чишелү. *Ильяс Егор Кононовичның әкият капчыгы әледән-әле чишелә торуга күнегеп бара иде инде ---.* Б.Камалов

**Чишелә төшү** Бераз чишелү. *Сер йомгагы исә көтмәгәндә бераз чишелә төште.* Шәһри Казан

**Чишелеп бару** Бер-бер артлы, билгеле бер тәртиптә чишелү. *Вакыйгалар логик рәвештә бер-берсенә бәйләнеп*

*чишелеп баралар, һәм алар барган саен үсәләр, көчәяләр.* М.Җәлил. *Проблемалар, чыннан да, күп, алар үз чираты белән чишелеп бара.* Бөгелмә авазы

**Чишелеп бетү** Тулысынча чишелү. *Аның әнә шулай үтә ягымлы булуы миңа бик ошый, шулай бөтен барлыгы белән балкып, ничектер бөтенләй чишелеп бетеп, чын күңелдән елмаюы да сөйдерә иде.* Г.Бәширов. *Ә эти-әни үзләренең җилкәләрендә безнең һичкайчан чишелеп бетмәс мәсьәләләребезне чишәләр.* А.Нәҗми

**Чишелеп килү** Соңгы арада чишелүгә таба бару; әлегәчә өзлексез чишелү. *Республика программаларында, грантларда катнашып, бу сораулар күпмедер күләмдә чишелеп килә.* Якты юл

**Чишелеп китү** Кинәт чишелү. *Аның сары күлмәк өстеннән кигән елтыр кара жилеты чишелеп киткән, чалара башлаган тузгак чәче маңгаена төшкән.* Г.Бәширов. *Менә баланың юрганы чишелеп китә, Бикәнең ботларына уралып, барырга комачаулый.* З.Зәйнуллин

**Чишелеп кую** Тиз генә чишелү. *Менә шуннан компьютер хикмәтләре чишелде дә куйды.* З.Мурсиев

**Чишелеп тору** Даими рәвештә, булган берсе чишелү; хәзерге моментта чишелү. *Шул рәвешле авылларда тормыш дәвам итә, килеп туган проблемалар чишелеп тора, киләчәккә планнар корыла, яңа баскычлар салына.* Бөгелмә авазы

**ЧИШЕНДЕРЕП** *рәв. сөйл.* Ачыктаначык, яшермичә. *Бөтенесен шулхәтле чишендереп, аты-юлы белән язалар ки, медицина дәреслекләрең бер якта торсын.* М.Маликова

**ЧИШЕНДЕРҮ** *ф.* 1) Кемнең дә булса өс, аяк киемен салдыру. *Гайрәт орды да, соңра, ятмак булып, Гөлбануга аягын чишендерергә кушты.* Г.Ибраһимов. *Киякнең өстен-башын чишендергәннән соң, су салып торып, кулын юдырасы икән.* Г.Бәширов // Анадан тума, ялангач калдыру. *Хикмәтне, авыл җыенында чишендереп, чыбык белән суктыруның икенче елында булды бу хәл.* А.Шамов. *Галим, --- урынынннан сикереп торып, авыруларны операциягә кертер алдыннан чишендерә торган бүлмәгә таба атлады.* Г.Әпсәләмов

2) *күч.* Мал-мөлкәтне көч кулланып тартып алу яисә яшерен рәвештә урлап китү; талау. *Мөгаен, бу бәндә элек Норвегиядә квартира басып, төнлә кешеләрне чишендереп йөргәндер ---.* Г.Әпсәләмов. *Фатирны тәмам чишендергән карак.* Н.Гыйматдинова

3) *күч.* Бәяләрне чамадан тыш күтәрү; соңгы акчасын алу, талау. *Чишендерәләр, мәйтәм, халыкны!* Д.Гыйсметдин // Бик ярлыга калдыру. *Дөнья мине чишендерде, мин шып-шыр, анадан тума ялангач калдым...* А.Гыйләҗев

4) *күч.* Бөтен булган әйберне алу, кырып-себереп алу, берни калдырмау. *Кем әйтмешли, күчтәнәчкә яулык тотып кайталар да чишендереп китәләр.* К.Кәримов

5) *күч.* Бик текәлеп, оятсызларча карау. *Бу – --- чибәр хатынга ашардай булып, ир-ат теле белән әйткәндә, аны чишендереп каравы иде.* Р.Кәрами

6) *күч.* Бик әйбәт тану, билгеләү; үтәдән-үтә күрү. --- *тыелган әйберләр алып керү турында фикер йөрткән кешене ул әллә нинди нечкә приборларга караганда да төгәл «чишендерә».* К.Булатова

7) *күч.* Ачу, тулысынча күрсәтү (авыз, тешләр тур.). *Утыз ике тешеңне аңкауга кадәр чишендереп, алай шаркылдап көлү килешми, туган.* М.Галиев

**Чишендерә башлау** Чишендерергә тотыну. *Шулай да чишенми яту мөмкин булмаганга, Гөлбану Закирны чишендерә башлады.* Г.Ибраһимов. *Сабирҗан тиз-тиз генә Миңлегөлне чишендерә башлады.* М.Хәсәнов

**Чишендерә тору** Әлегә чишендерү. *Пәтих, син ник терәлеп каттың, чишендерә тор Борнаш Тустыгановичны!* Р.Сәгъди

**Чишендереп ату** Тиз-тиз чишендерү. *Ике санитар йөгереп килеп, иң элек аны анадан тума чишендереп аттылар, өр-яңа күлмәк-ыштан кидерделәр.* М.Хәсәнов

**Чишендереп бетерү** Тулысынча чишендерү; бик нык чишендерү. *Кыз кияүне әүвәле чишендереп бетергәч, аннан үзе чишенә башлый.* К.Насыйри. *Әгәр алга таба да мондый абзыйлар болай комсызлансалар, илгә кайтып җиткәнче аны тәмам чишендереп бетерергә дә мөмкин иделәр.* Ф.Яхин

**Чишендереп җибәрү** Кинәт яки тиз генә чишендерү. *Өйгә керүгә, бала шыңшый башлаган иде, чишендереп җибәргәч, күзләрен зур ачып, ялтыравык нәрсәләргә караштыра башлады, шым булды.* М.Хәбибуллин

**Чишендереп кую** Кинәт яисә алдан чишендерү. *Яз чишендереп куйды үзләрен.* К.Кәримов

**Чишендереп ташлау** Тиз-тиз яки дорфа рәвештә чишендерү. *Бар киемнәрен чишендереп ташлый.* Әкият. *Бу минутта ул теләсә кемне шулай тиз генә чишендереп ташлый алыр кебек иде.* Р.Вәлиев

**ЧИШЕНМӘЛЕК** *и.* 1) Чишенү, өске киемнәрне элеп калдыру бүлмәсе; гардероб. *Соңга калган вәкилләр, кунаклар түбән катта, чишенмәлек янында, ашыгыч-ашыгыч тыш киемнәрен салалар да, кызыл кәгазьләрен күрсәтеп, югары залга агыла баралар.* Г.Ибраһимов

2) Өс киемнәрен берәр махсус эш, спорт һ.б.ш. киемгә алмаштыру урыны. *Ә әлегә ул бары тик Австралиядә, диңгез буенда күренә – монда кызык пляж чишенмәлеге урнаштырылган.* Күрше

**ЧИШЕНҮ** *ф.* 1) Өске киемне салу, өсне салу. *Яшьләр, чишенеп, өстәл янына уздылар.* А.Алиш

2) Киемнәрне тулысынча салып ялангач калу. *Нишләптер, баш әйләнеп китте дә егылдым... уянып китсәм... тфү-тфү, сикереп тордым дип әйтмәкче идем, күрәм: чишенгәнмен, күлмәксез басып торам.* А.Гадел

3) *күч.* Ябык кием кию гадәтеннән баш тарту, ачыграк кием киюгә гадәтләнү

**Чишенә бару** Торган саен чишенү. *Бер татар җырчысы белән Мисыр студенты гына түгел, мөселман халыклары гомумән әкренләп чишенә бара хәзер.* Шәһри Казан

**Чишенә башлау** Чишенергә тотыну. *– Утырып тор шушында, – диде Хәерлебәнат һәм читкә китебрәк чишенә башлады.* А.Гыйләҗев. *– Ярар, – диде Айзат гадәттәгечә тыныч кына һәм чишенә башлады.* А.Фәләх

**Чишенә тору** Әлегә чишенү. *– Алай булгач, син бар, битеңне агартып юып кил, ә мин чишенә торам, – дигән чыпчык.* Ф.Яхин

**Чишенеп ату** Бик җитез генә чишенү; кинәт чишенү. *Йосыф тиз генә чишенеп атты да Рәмилә янына кереп чумды.* Г.Гыйльманов

**Чишенеп бетү** Тулысынча чишенү. *Хәерлебәнат, чишенеп беткәч, аңа карады да кычкырып көлеп куйды ---.* А.Гыйләҗев. *Гамил иң соңыннан чишенеп бетсә дә, суга аягын беренче булып тыгып карады.* А.Тимергалин

**Чишенеп җибәрү** Бераз чишенү. *Рәхәтләнеп чишенеп җибәр, Аллага шөкер, өй җылы.* А.Гыйләҗев

**Чишенеп куюю** Алдан ук чишенү. *Әлбәттә, кызлардан алдарак чишенеп куйды Билал ---.* М.Вәлиев

**Чишенеп ташлау** *к.* **чишенеп ату**. *Атауга чыктылар да өсләрен чишенеп ташладылар.* А.Тимергалин. *Бөтенләй чишенеп ташлый бу.* А.Хәсәнов

**Чишенеп ыргыту** *к.* **чишенеп ату**. *Кәнфитләнеп торыр чак түгел, без, аны-моны уйлап тормастан, тиз-тиз чишенеп ыргыттык.* А.Гыйләҗев

**ЧИШМӘ** *и. фар.* 1) Җир астыннан бәреп, тибеп чыга торган су чыганагы; кизләү. *Мичкә ягарга утын кисәсе, малтуар карыйсы, ишегалдын себерәсе, тирес түгәсе, кар көрисе, чишмәдән су алып менәсе бар.* В.Нуруллин

2) Шундый чыганактан чыккан зур булмаган су агымы; инеш; гөрләвек. *Кояш кыздыра, кошлар сайрый, чишмәләр чылтырап ага.* А.Алиш. *Гүя бу мөкатдәс елгаларның суларын түгел, хәтфә болынлыктагы чишмәләребезнең бер йотым суын да бүген мин ширбәт итеп эчәр идем.* Г.Кутуй

3) Кайбер сыек нәрсәләрнең агымы. --- *шәһәр читендә чүп аунап ятмасын, булдыксыз операторлар гаебе белән түгелгән нефть чишмәләре акмасын ---.* Г.Ахунов

4) Ургылып чыга торган һәртөрле сыеклык. *Маңгаена ядрә кыерчыгы эләгеп яраланган Лайош та, сиптереп аккан кан чишмәсен куллары белән аралый-аралый, --- сазлыклар ягына таба торып чапты.* В.Имамов

5) *күч. кит.* Нәрсәнең дә булса чыганагы, башлангычы; нигезе. *Акмый тышка мәгънәләр – кипкән күңелнең чишмәсе; Калган урнында һәлакәт чокры, баткаклык күрәм.* Г.Тукай. *Ә минә яз һәм көз көннәрендә минем иҗат чишмәм ургый башлый.* И.Юзеев

◊ **Чишмә башы** *к.* **чишмә** (*5 мәгъ.*). *Тәүфикъ Әйди иҗатының чишмә башы 1967 елга барып тоташа.* Б.Камалов. *Гомумән, «Инкыйраз» – татар әдәбиятының гына түгел, бөтен татар мәдәниятенең, татар ренессансының чишмә башы ул.* А.Тимергалин. *Бу әдәпнең чишмә башы кайда, Агып килә кайсы чорлардан?..* Г.Морат

**ЧИШҮ** I *ф.* 1) Бәйләнгән бау, шнур, төенләнгән җеп һ.б.ш.ны сүтү, очларын ычкындырып аеру. *Аннары --- кроссовкаларын салырга иелде. Шнурларын чиште.* Җ.Юныс

2) Төрелгән, урап куелган әйберне сүтү, аның бавын ычкындыру. *Әниләре таң белән торып әзерләгән, сый салынган төенчекне чишеп, сыйланып алгач, күлдә су коендылар.* А.Хәйретдинова

3) Берәр нәрсә тирәли уралган әйберне сүтеп алу. *[Хатирә апа] Ияк астыннан бәйләгән яулыгын чишеп, яшь киленнәрчә, колак артыннан кайтарып бәйләп куйды.* Г.Әпсәләмов. *Плащын салды, шарфын чишеп элде...* Г.Гыйльманов. *Ут сүнгәч, Шельга яткан җиреннән сикереп торды да савыгып җитмәгән уң кулы белән, теше белән бинтны чишәргә кереште.* А.Толстой

4) Киемнең төймәсен, каптырмасын һ.б.ш. ычкындыру, ычкындырып ачу. *Пальто якасын ычкындырды, төймәләрен чиште [профессор].* Г.Әпсәләмов. *– Кәнишне, – ди егет һәм акрын гына кызның күлмәк изүен чишә.* З.Мәхмүди

5) Дөрес җавапны табу. *Рәфгать белән кара-каршы утырып, физикадан мәсьәлә чишәбез.* А.Гыйләҗев. *Солтанъяр бу хакта уйлангалап йөрсә дә, башваткычны чишә алмады.* З.Мурсиев

6) *күч.* Берәр мәсьәләне, проблеманы хәл итү, ачыклау. *Космосны аңлагач, без гомумпланетар, гомумкешелек мәсьәләләрен дөресрәк чишәрбез, тизрәк хәл итә алырбыз.* А.Тимергалин. *Атнага ике мәртәбә җыйналуны дәвам итәбез – чишәсе проблемалар күп.* З.Зәйнуллин // Берәр нәрсәне ачыклау, белү. *Искәндәр чәй янында ук, үзен борчыган серне чишү теләге белән, Гөлсем апага берничә сорау биреп караган иде.* Г.Гобәй

7) *күч.* Берәр яшерен булган нәрсәне, серне сөйләү; үзенең хәлен, уйниятләрен сөйләп бирү. *Ничек итеп җанында кайнаганын чишсен соң ул?* А.Вергазов. *Хаммат абый, бу серемне сиңа гына чишәм.* А.Хәсәнов. *Үзләренең очында ялгыз башы яшәүче карт кызны ярәштерергә ниятләвен әтигә чишә.* К.Миңлебаев

**Чишә бару** Бер-бер артлы чишү. *– Эчкән өчен алып аттылар үзен эшеннән, – дип, берни яшермичә, күптәннән таныш кешесенә сөйләгән кебек, иң нечкә серләрен риясыз чишә барды.* Т.Галиуллин. --- *иң мөһиме – ул проблемаларны әдәбият үзе чишә бара.* М.Вәлиев

**Чишә башлау** Чишәргә керешү. *Аның башында үзенчә авыр мәсьәлә иде: бу чуалчык трагедияне кай ягыннан чишә башларга?* Г.Ибраһимов. *Мәсьәләне чишә башлаганчы ук бозып ташларга мөмкин иде.* В.Нуруллин

**Чишә бирү** Бернигә карамый чишү. *Хикмәтле моторларның серен ул тагын да дәртләнебрәк чишә бирде.* Г.Әдһәмова

**Чишә килү** Әлегәчә эзлекле рәвештә чишү. *Икенче язучы, иҗатының башында ук тормышның үзгеннән бер проблема суырып алып, шуны әсәрдән-әсәргә тулырак, күп яклырак һәм тирәнрәк, ышанычлырак итеп чишә килсә, --- бу вакытта инде без төпле язучы белән очрашуыбызны тоябыз ---.* М.Вәлиев. *Чөнки Татарстан халкы гомергомердән – авырлыклар килгәндә дә, шатлыкта да – бердәм булып, мәсьәләне уртага салып, бергәләп фикерләшеп чишә килде.* Татар заманы

**Чишә тору** Бер-бер артлы чишү; әлегә чишү. *Бераз гына көтә тор, Янчык бавың чишә тор.* Т.Гыйззәт. *Лenaның хатлары торган саен кыюрак була барганнар, ул мине үзенең тирән фикердәше итеп санаган, шикләнмәгән, курыкмаган, бар булган серләрен чишә торган.* А.Гыйләҗев

**Чишә төшү** Бераз гына чишү. *Чишелмәгән төеннәрне Тешем белән чишә төштем.* Ф.Яруллин. *Абыстай, сөйләм тәмәнә керер алдыннан, әүвәл күлмәк итәкләренә кадәр җыя төшәр, баш яулыгын чишә төшәр һәм, ике кулын күтәреп, Аллаһыга дога кылыр иде.* М.Хәбибуллин

**Чишеп алу** Тиз арада чишү. *Таһирҗан муенындагы кульяулык-шарфын чишеп алды да моңсу гына утырган Гәүһәриянең муенына урады.* Г.Әдһәмова

**Чишеп ату** Җәһәт кенә, кызулык яки ялгышлык белән яисә көтмәгәндә чишү. *Хәзер чишеп атабыз аны!* А.Гыймадиев. *Серне ялгыш кына чишеп атым бит.* В.Нуриев

**Чишеп бару** Булган берсен бер-бер артлы чишү. *Ә мин, ни дисәң дә, XX гасыр гәзитләрендә басылган шахмат мәсьәләләрен гел чишеп бара идем.* А.Тимергалин

**Чишеп бетерү** Тулысынча чишү. *Билгеле, андый вак-төякләр бихисап күп, аларны чишеп бетерү мөмкин түгел...* А.Тимергалин. *Ләкин ул да проблеманың барлык якларын чишеп бетерә алмый әле ---.* К.Гыйззәтов

**Чишеп җибәрү** Кинәт чишү. *Нәфисә шәлен чишеп җибәрде дә, торып, урындыгының артына таянды.* Г.Бәширов. *Аның хәзер үк кемнедер, үзен аңлый торган кешене эзләп табасы, күкрәгенә бөялгән төерне чишеп җибәрәсе килде.* А.Вергазов

**Чишеп куюю** Алдан ук чишү; тиз генә чишү. *Шуны әйтергә кирәк, Нургали азык мәсьәләсен күңеленнән катгый рәвештә чишеп куйган иде.* Ә.Еники. *Алдан ук серне чишеп куярга тиеш булмасам да, үзеңне якын иткәнгә әйтәм инде алайса ---.* В.Нуруллин

**Чишеп салу** Көтмәгәндә чишү. *Кала башлыгы булып алган сатлык Анастасий инде кайсарлар сараендагы серне дә чишеп салды ---.* В.Имамов

**Чишеп ташлау** *к.* **чишеп ату**. *Кайтып, бөтенесен чишеп ташлаганмы әллә теге пырдымсыз зат?!* А.Гыйләҗев. *Беркадәр вакыт маймыл тыз да быз килеп йөри, аннары кинәт «мәсьәлә»не чишеп ташлый.* А.Тимергалин

**Чишеп тору** Әле, хәзер чишү; даими чишү. *Җитмәсә, Сания узган юлда бастырык бауларын чишеп торам.* Р.Рахман

**Чишеп яту** *сөйл. к.* **чишеп тору**. *Мин бәрәннең арканын чишеп ятканда, урыс авылыннан бер марҗа түти баягы сары чәчле кыз белән аһылдап йөгереп килде дә дуңгыз янында иелә-бөгелә такмакларга тотынды.* Г.Бәширов. *Николай Сергеевич белән мин инде ничәмә-ничә бөтендөнья проблемаларын чишеп ятканда, Шәех килеп керде.* Ә.Мушинский

**ЧИШҮ** II *и.* Нинди дә булса мәсьәләне хәл итү, берәр мәсьәләнең, башваткычның җавабын табу максаты белән башкарыла торган акыл эшчәнлеге. *Н.Исәнбәт бу вакыйганы сатира планында чишүне күздә тоткан.* М.Җәлил

**ЧИЯ** I *и.* **1.** 1) Гөлчәчәклеләр семьялыгыннан куе кызыл төстәге сусыл җимеш бирә торган күпьеллык агач яки куак. *Алмагачлар һәм чия чәчәк атканда, тау битләвенә кабат ап-ак кыш әйләнеп кайткандай була.* А.Тимергалин. *Әнә гөлҗимеш куаклары, шомырт-балан агачлары, чикләвек, чия рәтләре...* Г.Гыйльманов

2) Шул агачның җимеше. *Бергә урманга, чиягә йөрдек.* Г.Кутуй. *Тубал тотып чия сатарга чыгармы?* А.Гыйләҗев

**2.** *с. мәгъ.* Шул үсемлекнең җимеше төсле. *Шомырт күзле, бал авызлы, чия иренле Фарзанасы турында уйлый.* Г.Кутуй

**ЧИЯ** II *рәв. к.* **чияли**. *Бауны чия бәйләү*

**ЧИЯ́ КӨРӘН** *с.* Кызгылт көрән. *Ахырда, күптән киелмәгән чия көрән күлмәгемне алдым.* Ф.Садриев

**ЧИЯ́ КЫЗЫЛ** *с.* Карасу кызыл, куе кызыл. *Чия кызыл иренле, ясалма бөдрә чәчле, тулы беләкле тәбәнәк кенә бер ханым, күбәләктәй очынып, аңа каршы килә иде.* Ф.Җамалетдинова. *Фатыйманың, ишектән керүгә, күзенә матур чия кызыл күлмәк чалынды, ул аңа беренче булып үрелде.* З.Кадыйрова

**ЧИЯЛӘНДЕРҮ** *ф.* 1) Бәйләнгән бауны һ.б.ш. нәрсәләрне чишә алмаслык хәлгә китерү, чәбәләндерү; бик нык төенләндерү. *Хәтерлим, ник хәтерләмәскә... Күлмәгемнең җиңен чияләндереп, каз боты кимерткәнең дә истә әле...* Р.Мөхәммәдиев

2) Чуалту, киезләндерү. *Чияләндерсә [чәчне] – бетте, тарак мәңге кермәячәк!* Ф.Яхин

**ЧИЯЛӘНҮ** I *ф.* 1) Бәйләнгән бау, җеп чишә алмаслык хәлгә килү, чияли бәйләнү. *Җирән биянең чөйлек бавы чияләнгән...* Г.Ибраһимов

2) Чуалу, чәбәләнү. *Кәҗә генә көяләнгән – Сакалы шул чияләнгән.* Н.Әхмәдиев. *Безнең Уфа ягындагы кара халык телендә: «Әгәр дә атның чияләнгән ялын берәү тарап куйса, ат иясе ачуланып, бер минут тормый кача, имеш тә, шул көннән игътибарән ат хуҗасының бәхете китә, фәкыйрьләнә», – дигән сүз бар.* Б.Мирзанов

**Чияләнә бару** Торган саен чияләнү. *Ә бу төен торган саен ныграк тартыла һәм чияләнә бара.* Ә.Еники

**Чияләнеп бетү** Бик нык чияләнү. *Карады да җилләрдә җилфердәп чияләнеп беткән чәчләрен тарарга тотынды.* Ф.Яруллин. *Ниһаять,ката табыла, ләкин Хуҗин катаны кия алмый интегә, катаның бавы чияләнеп беткән була.* Р.Батулла

**ЧИЯЛӘНҮ** II *ф.* Чия куагында (агачында) җимеш барлыкка килү, төенләнү. *Чия, чия, чия чияләнгәндә, Чия матур алсу була яңгыр сибәләгәндә.* Җыр

**Чияләнә башлау** Чияләнү билгеләре күренү

**ЧИЯЛӘП** *рәв. к.* **чияли**. *Ул проблемалар төене җәмгыятебез хәленә торышына чияләп бәйләнгән.* Ш.Галиев

**ЧИЯЛЕК** *и.* 1) Чия куаклары, агачлары үсә торган бакча; чия үсә торган урын. *Урманнарда җиләк-җимеш үсә, берничә гектарга җәелгән чиялекләр, карлыган һәм балан, шомырт һәм бөрлегән куаклары каплаган әрәмәлекләр.* М.Юныс. *Чәчәкләрен койган чиялекнең итәгендә әллә кар ята?!* З.Мансуров

2) Чия төс. *Химиядән соң ул иреннәренең матур чиялеген югалтты.* З.Кадыйрова

**ЧИЯЛИ** *рәв.* Очыннан тартканда чишелмәслек итеп, чуалтып, чәбәләндереп (бәйләү, төенләү тур.). *Бер кызык уйлап куйдым – Дустымның күлмәк җиңнәрен Чияли бәйләп куйдым.* Ш.Галиев

**ЧИЯЛТҮ** *ф. сөйл. к.* **чияләндерү**. *Котылалмый Җик агай тик, өзгәләнә, Ничек кирәк шулай шашып тартыла ул, Чияләнгән бауны кабат чиялтә ул...* Ф.Яхин

**ЧЛЕН** *и. рус к.* **әгъза**. *Ашыктырдыгыз, ашыктырдыгыз, идарә членнары белән бәхәскә кердек.* А.Гыйләҗев

**ЧЛЕНЛЫК** *и. к.* **әгъзалык**. *Егерме беренче июньдә партия оешмасы аны партиягә членлыкка кандидат итеп алган.* Г.Әпсәләмов. *Чөнки әле кешенең барлыгын, кем икәнлеген раслый торган таныклык, паспорт, членлык һәм хәрби билетлар – һәммәсе дә кулдан языла.* Х.Сарьян

**ЧОБА** *и. гар.* Киндер тукымадан тегелгән, эчлеге булмаган кием, җилән. *Озын чобасын, селтәп, киң җилкәләренә элде, күлмәк җиңнәрен тотып, киндер җиләненең җиңнәрен беләзегенәчә төшерде, чобасы-җиләне изүен каплады, билбавын кысып ук буды.* М.Хуҗин

**ЧОБАЛУ** *ф. диал. к.* **чуалу**. *Бераз читтәрәк, бөтен басуны каплап, күбесенә пар ат җигелгән тарантас, арбалар, иярле атлар, алар тирәсендә чобалган ярлы казакъ ирләре күренә.* Г.Ибраһимов

**Чобала башлау** Чобалырга тотыну. *Расходлар күбәйгәчтен, чобала башлыйдыр хисаплар.* Ш.Мөхәммәдев

**Чобалып бетү** Тәмам чобалу. *Ләкин Сахибкә ул башка – элеккенең хәрабәсе кебек күренде: чәч, тузып, маңлайга төшкән, күптән таралмый чобалып беткән, йөзе ябыгып караңгыланган, --- ирен, күз төпләре җыерчыкланган...* Г.Ибраһимов

**ЧОБАР** *с. диал. к.* **чуар**. *Әмма монда кырык корама, йөз ялгауны җыеп, чобар юрган тегәләр.* Г.Ибраһимов. *Әмма ләкин авылыбыз халкы бик чобар.* С.Поварисов

**ЧОБАРЛАНУ** *ф. диал. к.* **чуарлану**. *Озак яңгырдан, каты сагындырудан соң матур йөзен ачкан, кояшның нурларын киң күкрәгендә иркәләп уйнаткан сыман күренгән тигез, шома Идел өсте төрле төстәге көймәләр белән чобарланды.* Г.Ибраһимов

**Чобарланып бетү** Бик нык чобарлану. *Кыңгырау тавышына өйдән бер кыз бала атылып чыкты да яңгыр белән юешләнеп беткән атларга,*

*баштанаяк пычранган тарантаска, өсләре, йөзләре балчык белән чобарланып беткән кунакларга карап аптырап калды ---.* Г.Ибраһимов

**ЧОБАРЛА́У** *ф. диал. к.* **чуарлау**. *Ишектән кергәч тә уң якта ап-ак итеп агартылган зур мич бар, шуның алды чобарлап эшләнгән бик зур һәм яңа чаршау илә бүленгән.* Г.Ибраһимов

**Чобарлап бетерү** Тәмам чобарлау. *Бу өй башка өйләргә караганда карсак, буялмаган, шкатурлары кубып беткән, стенасына күмер вә акбур берлән әллә ниләр язып чобарлап бетерелгән ---.* Г.Ибраһимов

**ЧОБАРЛЫК** *и. к.* **чуарлык**. *Мәнә сезгә бер чобарлык.* С.Поварисов

**ЧОГЫН** *и. бот.* Алабутачалар семьялыгыннан корылыкка, көчле җилләргә чыдам чүл үсемлеге. *Тоз яратучы куаклар – чогын, черкез, алар белән бергә ак саксаул үсә.* А.Фәткуллин

**ЧОГЫР** *и.* Дагстанлыларда мандолинага охшаш кыллы музыка коралы. *Мәһди үзләренең чогыр дигән коралларында «Гашыйк Кәрәм»не чирттереп моңлана иде.* Ш.Камал

**ЧОЖ** *иярт.* 1) Табада ашамлык кыздырган, печән чапкан һ.б. очракларда барлыкка килгән кыска тавышны белдерә. *Тирә-юньдә яңадан шаушу, яңадан сварка авазлары кабынды. Чажж... Чожж...* Ә.Шәмин

2) Бик тиз хәрәкәт итү рәвешен белдерә. *Керү белән – чож өстәл астына.* А.Хәсәнов

**ЧО́Ж ИТҮ** *ф.* Чож сыман тавыш чыгару. *Аркам манма су булды, ә балтам, ышанасызмы, ут кебек кызган иде: үзебезгә чыгып җиргә ташлавым булды, кар чож итеп куйды...* А.Гыйләҗев. *Көч-хәл белән тиешле урынга барып җиткәндә, кинәт күк яктырып китте, чож итеп яктырткыч ракеталар алларына ук төшә башлады.* Р.Кадыйров

**ЧОЖЛА́У** *ф. к.* **чож итү**. *--- ярты капны исраф иткәч, ут күксел, черек салам учмасына йөгерде, ак пар һәм зәһәр ис таратып чожлады.* А.Гыйләҗев. *Көндез яуган кар эреп бетә язган, шуңа күрә җебегән карны лыжырдатып, юеш асфальттан чожлап, гөрләп, машиналар да сирәк үтә.* Р.Кәрами

**Чожлап тору** Әле чожлау. *Бәйрәм килгән тагын да: Чөмергән аракысын да, Чожлап торган балын да.* А.Галкин. *Ипи салган, бәлеше чожлап тора, кер юган, мунча яккан.* Туган як

**Чожлап утыру** *к.* **чожлап тору**. *Соңарып кына учак тергезделәр, ботаклар чи, утын дымлы иде, учак кабына алмыйча, ачы ис чыгарып шактый чожлап утырды.* Я.Зәнкиев

**ЧО́Ж-ЧОЖ** *иярт.* Табада ашамлык кыздырганда, печән чабу кебек кабатлаулы хәрәкәтләр ясаганда барлыкка килгән тавышны белдерә

**ЧО́Ж-ЧОЖ ИТҮ** *ф.* Чож-чож сыман тавыш чыгару

**ЧО́Ж-ЧОЖ КИЛҮ** *ф. к.* **чож-чож итү**

**ЧОЖЫЛДА́У** *ф. к.* **чыжлау**. *Кояш кыздыра башлагач кына чожылдап куралар арасыннан чыкты да, мөлдерәп тулган чиләген салкын күләгәгә куеп, өстенә әрекмән япты.* М.Мәһдиев. *Иң элек почмаклар караңгыланды, стенада Нурулланың иләмсез, гарип шәүләсе уйнады-уйнады да, ут, чожылдап, бөтенләй сүнде.* А.Гыйләҗев

**ЧОКУ** I *ф.* 1) Берәр корал белән агач, сөяк һ.б.ш. өслекләрдә кисеп, уеп тирән эз калдыру; өслектә чокыр барлыкка китерү. *Сез Рәхиләгә шундый җиңел, шундый җыйнак агач тагарак чокып биргәнсез.* А.Гыйләҗев. *[Сафа] Аякларын алга турайтып салып, кесәсеннән тәмәке янчыгы, чия ботагыннан үзе чокып ясаган челем алды.* Л.Зөлкарнәй

2) *сөйл.* Җирне уеп, казып һ.б.ш. юллар белән чокыр ясау. *– Мин бик шат, – диде шәһәр малае, туфли очы белән җирне чокып.* А.Тимергалин. *Чучкалар җир чокыйлар, Ә үрдәкләр, ә казлар Көн дә үлән чукыйлар.* Р.Миңнуллин. *Фронтовик, чын окопны хәтерләткән, чирәмлекне кеше буе чокып кергән бер уйсу ярны сайлап алды да урнашу ягын кайгырта башлады ---.* Г.Гыйльманов

3) *сөйл.* Күмелеп калган яисә тирәнлектә урнашкан нәрсәне казу, казып чыгару. *– Бәрәкәт, алтын чокыйсызмы әллә, бик тырышасыз! – дип көлде ул.* А.Гыйләҗев. *Әти, шахтага төшеп, күмер чокый, әнием күмер озату станциясендә хисапчы булып урнаша.* З.Хәким

4) Берәр нәрсәнең эченә керү өчен тишү. *Миенә корт чокып кергән диярсең, чигә турында гына нидер безелдәп, чыңлап тора башлады.* Г.Гыйльманов

5) Очлы үткен әйбер белән төртеп тишү, төртеп чыгару; кисеп алу. *[Сәлимә:] Күзеңне чокып чыгарырмын!* А.Гыйләҗев

6) Берәр нәрсәне зарарлы, кирәк булмаган әйберләрдән арындыру; чистарту. *Сезнең курстагы атка охшашлы бер таза егет баганага сөялгән дә, борынын чокып, тик карап тора.* М.Юныс. *Көн саен бер икмәк – фәлән сум, сөт – фәлән сум, сагыз – фәлән тиен, теш чоку чырасы – фәлән тиен...* Байрак

7) *күч. сөйл.* Эзләү, җентекләп өйрәнү, тикшерү. *Менә шунысын алу өчен, безнең оешмалар синең нәселеңне җиде бабаңа чаклы чокып тикшерә, кырыкмаса-кырык иләк аша җилкеп чыгара, ди.* В.Имамов

◊ **Чокып чыгару** 1) Онытылган, югалган әйберне әллә кайдан табып чыгару. *Әллә нинди иске чабаталар, ертык күлмәк чокып чыгардылар ---.* В.Имамов; 2) Үткәндә булганнарны кабат искә төшерү. *Теге вакыйганы чокып чыгаралар икән... Бетте баш.* Г.Афзал

**Чокый башлау** Чокырга тотыну. *Аларның кайсы түбән карап, кулындагы таягы белән җирне чокый башлады.* М.Әмир. *Чатлы киртә баганасыннан атлам белән үлчәп, икенче ачыклыкны чокый башладык.* А.Гыйләҗев

**Чокый бирү** Бернигә карамый чоку. *Бала әйтерсең юк иде: шым гына бер почмакка утыра да үзалдына ни дә булса чокый бирә, ни ашарга сорамый, ни еламый.* З.Кадыйрова

**Чокып алу** Тиз генә чоку. *Әнә Кондызбай юан аяклары белән балчыкны чокып ала да тиз-тиз артка ыргыта.* К.Тәхау

**Чокып ату** Бик тиз чоку; вәхшиләрчә чоку. *Шигырь күңел чәчәге генә булса, Рудакиның якты күзләрен караңгылык чокып атмас иде ---.* Р.Харис

**Чокып бетерү** Бик нык чоку, бөтенесен чоку. *Дөрес, бу турыда беркем сөйләнми, кайчак беркем белми дә, белсә, һичшиксез, чит ирне кочакка алган хатынның яшәрлеген калдырмаслар, күзләрен үк чокып бетерерләр.* Р.Рахман

**Чокып кую** Алдан ук чоку. *Зөбәйдә бар көченә алдан чокып куйган тakталарны этеп җибәрде ---.* И.Сиражи

**Чокып ташлау** Бик тиз генә чоку. *Һәм җитез генә икенче кечерәк кыярның да эчен чокып ташлады.* Ә.Еники

**Чокып тору** Даими чоку; әле, хәзер чоку. *Гыйльман сөйләшкәндә, Биктимер ачуыннан чалгы сабы белән җирне чокып тора.* А.Алиш. *Бозны без, аяк таймасын өчен, һәрдаим чокып торабыз.* Якты юл

**Чокып чыгу** Һәммәсен чоку. *Бөтен чүп савытын чокып чыкты...* Р.Ахунова

**ЧОКУ** II *и.* Металл, таш, агач, пыяла өслеккә махсус кораллар ярдәмендә

кисеп, уеп рәсем, язу, бизәк төшерү эше һәм сәнгате; гравировка. *[Габидуллиннар нәселе көмешчеләре] Нигездә, кою (литьё), чүкү (чеканка), чоку (гравировка), каралту (чернение), бөтерү (скань) техникаларын кулланып эшләгәннәр, шулай ук эмаль белән дә каплаганнар, инкрустация ясаганнар.* Милли-мәдәни мирасыбыз: Нижгар татарлары. *Ул линогравюра, агачны чоку, офорт, майлы буяу белән рәсем ясау, акварель куллана.* Алабуга нуры

**ЧОКЧУ** *ф.* 1) Чоку, казу. *Агач кайрысын чокчу*

2) *күч.* Каныгу, бәйләнү. *Малайны һаман чокчыйлар*

◊ **Чокчып чыгару** *к.* **чокып чыгару**. *Кызык та яза, газетага иң кирәкле кешеләрне, вакыйгаларны чокчып чыгара, ялгышмый, буталмый.* А.Гыйләҗев

**Чокчып алу** Бераз чокчу. *Мөнирнең җәй чыккан саен энесен үчекләп, чокчып алырга яратуын Идрис сизенеп тә өлгерде.* А.Гыйләҗев

**Чокчып тору** Әле, хәзер чокчу; бертуктаусыз чокчу. *Габделнурның ишеткәне бар: солдат-матросларны каты җәберләгән, берөзлексез чокчып торган сержант-старшиналарны, дембельгә бергә эләксәләр, поезддан тотып ыргытулар да булгалаган.* Р.Кәрами

**ЧОКЧЫНУ** *ф.* 1) Берәр урында казыну, эзләнү. *Авызын ачтырып куеп, әлеге тимер белән тамагына кереп китте, икенче тимер алып колак эчендә чокчынды, танау тишекләрен ихласлап өйрәнде.* К.Кара

2) Берәр нәрсәнең бөтен нечкәлекләрен ачыклау, җентекләп тикшерү. *Моны ачыклау өчен --- тарихның канлы боткасында казынырга, чокчынырга, тикшерергә, өйрәнергә --- [кирәк].* А.Хәлим

3) Төпченү, гаеп эзләү, бәйләнү, каныгу. *--- һәрбер төрле чын хезмәтченең эшеннән әлләниләр казынып, чокчынып гаеп эзли, яшь буын арасында җәмәгать эшләренә битарафлык фикерен урынлаштыра, хулиганлык тарата.* Г.Исхакый. *Җитте. Безнең нәселгә үк кереп чокчынма.* Л.Лерон

4) *күч.* Бик акрын эшләү, кыймылдау

**Чокчына башлау** Чокчынырга тотыну. *Теге кеше туп-туры кухня янындагы чүплек башына атлады һәм шунда чокчына башлады.* Г.Әпсәләмов

**Чокчынып йөрү** Озак вакытлар чокчыну. *Подъезд төбендәге чүп савытында нидер эзләнеп, чокчынып йөри иде бу бала кисәге.* Г.Гыйльманов

**Чокчынып килү** Әлегә кадәр чокчыну. *Мин бу хәреф мәсьәләсе өстендә башыннан бирле чокчынып килгән, уйланып яткан берәү булуым уңае белән, әрепләшү өчен түгел, аңлашу уе белән, бу турыда карашымны әйтеп калырга телим.* Г.Алпаров

**Чокчынып тору** Әле чокчыну. *Андый мөдирләр яңгырдан соң котырып үскән чебен гөмбәләре сыман адым саен бит инде, нәрсә кирәк-кирәкмәгәнгә дә чокчынып тора инде бу дип, мыек астыннан гына көлеп утырасыздыр, беләм.* Л.Ибраһим-Вәлиди

**Чокчынып яту** *сөйл. к.* **чокчынып тору**. *Тюрколог проф. Ашмаринның да чокчынып ятканы күренә.* Г.Алпаров. *Сез көне буе чокчынып ятканны Гатаулла бармак уйнатып кына башкарып ташлый!* Ф.Яхин

**ЧОКЫНУ** *ф. диал. к.* **чокчыну**. *Хәйдәр баштагы көннәрдә гел шунда чокынды, эшкә ярардай таза такталарны җилкәсенә күтәреп ихатага ташыды.* В.Имамов. *Әмма дә хәрефләрдән сүзләр җыя алмыйча шактый озак казынган, чокынган.* Ф.Яхин. *Алда баручылар кинәт кычкырып җибәрде: нииндидер җәнлек сумкалар янында чокына иде.* З.Мурсиев

**Чокына башлау** Чокынырга тотыну. *Тикшерү тәмам дигәннәр иде, әллә инде яңадан чокына башладылармы?* З.Мурсиев. *Илдар домофон шалтыравына җавап бирми, ә берничә минуттан фатирының ишегендә чокына башлауларын ишетә.* Әлмәт таңнары

**ЧОКЫР** *и.* 1) Җирдә казып ясалган урын. *Әле ярый эскерт төбендәге әрләнгән казыган чокырга аягы батып егылды, эшләпәсе тәгәри барып, сулы чокырга ауды.* А.Гыйләҗев. *Малай көрәген тагын да ныграк батырып казырга тотынды, чокырны шул якка киңәйтеп төште.* А.Тимергалин // Нинди дә булса максатлар өчен (берәр нәрсәне салып саклау һ.б.ш. өчен) махсус казылган урын; баз. *Кораблар өчен кайтарылган агачны адмиралтия тирәсендәге чокырда «тозлаганнар».* А.Тимергалин. *Беләсеңме, идән асты чокыры, еллар дәвамында күмелеп, җир белән тигезләшсә дә, казылмаган каты балчыктан барыбер аерыла икән.* А.Гыймадиев

2) Тирә-яктагы коры җир яки су төбе өслегеннән батынкырак булган урын, текә ярлы иңкүлек. *Аның үтә торган сукмагыннан өч-дүрт кенә сажин баргач, яр астына төшеп китә торган чокыр – текә яр бар.* Г.Ибраһимов. *Анда бер кечкенә агач үсеп утыра, ә тирәякта куаклык, әнә тегендәрәк тирән чокыр башлана.* А.Гадел // Яңгырдан соң транспорт, хайваннар изүдән барлыкка килгән вак батынкылык. *Тау менгәндә, без арбадан төшәбез, малкайларга авырга килмәсен дип, арттан этәбез, дегетле күчәр башыннан тотып күтәреп, тәгәрмәчне чокырдан чыгарабыз...* А.Тимергалин

3) Бомба, артиллерия снаряды, мина шартлаганда җирдә барлыкка килгән киң авызлы тирән батынкы урын. *Бөтен җирдә кап-кара снаряд чокырлары җәйрәп тора, күбесенә яшел су тулган.* Г.Әпсәләмов. *Шәһит киткән яугирләрне тиешле кадер-хөрмәт күрсәтеп җирләү мөмкинлеге булмаганлыктан, аларны туп ядрәләре ясаган тирән чокырларга рәт-рәт итеп тезеп җирләргә туры килде.* З.Мәхмүди

4) Берәр нәрсәнең тигез өслегендә бәрелү, сугылу һ.б.ш.дан соң барлыкка килгән уем, батынкылык. *Өрекләр ашалды, чикләвекләрнең истәлеге булып, урындык башларында бәләкәй чокырлар калды.* А.Гыйләҗев. *Ботканың уртасына, кашык йөзе белән чокыр ясап, май салган, ди.* Д.Салихов

5) Кеше тәнендәге, әгъзаларындагы табигый уем, батынкы урын. *Хәнәфинең тирән чокырларда утырган күзләре туктаусыз елтыраштылар, ул, борын яфракларын киереп, һава сөзде ---.* А.Гыйләҗев. *Бит очлары уймак чокыр, чокырлары алсудан, Буянган алсу түгел ул, эчтә кояш балкудан.* А.Хәлим. *Әнинең инде артыма килеп басканын җилкә чокырым белән сизгән идем, кинәт кенә борылып, аның күкрәгенә сыендым.* А.Әхмәтгалиева

6) Тештә бозылып барлыкка килгән тишек. *Шуны чәйгә манып, аңкауны ышкыганнар, авыру теш чокырына сарымсак яки киптерелгән ярканат порошогы куйганнар.* Ватаным Татарстан

7) *махс.* Оркестр өчен сәхнә алдында түбәндә, эчкә батырылып ясалган аерым бүлмә. *Гафу үтенеп, рәтләр арасыннан кысыла-кысыла, үз урыннарын табып утырганда, пәрдә ачылган һәм сәхнә алдындагы чокырда урнашкан оркестр кереш музыкасын түгәлләп килә иде.* Г.Әдһәмова

8) *сөйл.* Чынаяк. *Хәбиб алдына азрак кәбестә, зур чынаяк чокыры куелды.* Г.Ибраһимов. *Сөтне бик яратам мин. Савып кергәч тә ике чокыр тутырып*

*эчәм.* А.Гыйләҗев. *Карчык, күтәрелеп, түсен җуйган иреннәрен чокырның читенә тидерде.* А.Мансуров

9) *күч.* Кешеләрнең аралашуын кыенлаштыра торган киртә, арадагы якынлыкны юкка чыгара торган нәрсә. *Вә шулай итеп, аңлашу урынына ике арада зур бер аңлашылмау, ике арага бик ямьсез тирән бер чокыр казылды.* Г.Исхакый

**ЧОКЫРАЙТУ** *ф. сөйл. к.* **чокырландыру**. *Ә Диләфрүз, киресенчә, ирен почмакларын чокырайтып елмайды гына.* Г.Әпсәләмов. *Ул аякларын тизтиз кайнар комга күмгәләде, аннары, иңе белән комны чокырайтып, шунда сыенды.* Х.Камалов

**ЧОКЫРАЮ** *ф. сөйл. к.* **чокырлану**. *Бите тимгел-тимгел кызарган, утлы күзләре чокыраеп тирәнгә баткан ---.* А.Гыйләҗев. *Хәзер ул чүккән, черегән, бер урыны бүлтәеп калыккан, икенче урыны чокыраеп кергән.* Ф.Садриев

**Чокыраеп калу** Берәр нәрсәгә бәйле рәвештә чокырайган торышка килү. *Мае бетеп, төпләре чокыраеп калган бу күзләргә әйтеп аңлата алмаслык якынлык һәм үзенә күрә ниндидер бер кыенсыну тулган.* Казан утлары

**Чокыраеп китү** Кинәт яисә бераз чокыраю. *Кызның буй-сыны бик килешле, көлгәндә чокыраеп китә торган бит алмаларына сандугач оялардык иде.* Р.Газиз. *Көлгәндә аның ак типтигез тешләре ялтырый, ияк очлары чокыраеп китә – алар абыйсы белән бик охшашлар.* З.Кадыйрова

**Чокыраеп куу** Беразга чокыраю. *Елмайган чагында аның тигез кара кашлары югары чөелеп, маңгаенда байтак кына сырлар хасил булды, әмма иң хикмәтлесе – ике яңагы да матур булып чокыраеп куйган иде.* Э.Касыймов

**Чокыраеп тору** Әле чокыраю; даими чокыраю. *Тау түбәсе – ап-ак ташлык, үлән бик сирәк, урта бер җире чокыраеп тора.* Ә.Еники. *Гөлназ зифа буйлы, озын кара чәчле, елмайганда ике бите чокыраеп тора, шуңа күрә аерата сөйкемле күренә.* И.Нәбиуллина

**Чокыраеп чыгу** Кинәт һәм тулысынча чокыраю. *Аның күзләре йомылып бетә, җемелдәп, ап-ак тешләре күренә, бит алмалары чокыраеп чыга.* Г.Бәширов

**Чокырая бару** Торган саен күбрәк чокыраю. *Әхтәм абый белән Габделәхәт кырыйлары капчык киндереннән тегелгән, уртасы чокырая барып тегәрҗептән бәйләнгән озын колга саплы ятьмәне сүттеләр дә чапыр-чопыр суга кереп киттеләр.* Т.Нурмөхәммәтов

**Чокырая төшү** Бераз чокыраю. *Кибән очындагы чокырая төшкән урынга кереп яшеренергә ашыкты ул.* Р.Мөхәммәдиев

**ЧОКЫРЛАНДЫРУ** *ф.* Батынкы хәлгә китерү, чокыр рәвешен бирү; чокыр яки чокырчыклар хасил итү. *Йөзлебикә, бит урталарын чокырландырып, көлеп җибәрде.* Г.Бәширов. *Аның Дамиры да шулай, битен чокырландырып, балкып көлә иде.* Мәдәни җомга

**ЧОКЫРЛАНУ** *ф.* Батынкы хәлгә килү, чокыр рәвешен алу; чокыр барлыкка килү. *Тавыклар менеп актара торгач, җәй буена чокырланган түбә саламына яңаны өстәмичә, кыш чыгарлык түгел.* К.Кәримов. *Көз түшәгән асфальтлары язга чокырланып, җимерелеп бетә.* Маяк

**Чокырлана башлау** Чокырлану билгеләре пәйда булу. *Совхоз идарәсенең күп йөрүдән ашалып чокырлана башлаган баскычлары буйлап өске катка менгәндә, Рәфис катлаулы хис кичерде ---.* А.Вергазов

**Чокырланып бетү** Бик нык чокырлану. *Аның тубы моннан ике ел ярым элек Идел буе ярында, снарядлар шартлаудан чокырланып беткән ком өстендә тора иде.* Г.Кутуй. *Байтак урамнар чокырланып беткән, аларны әрем, алабута, билчән баскан.* В.Имамов

**Чокырланып калу** Берәр нәрсә ахырында чокырлану. *Бармак очы белән баскалаган тән тиресе, үз урынына кайтмыйча, чокырланып кала икән, димәк, бу кеше үлем ачлыгына дучар.* Г.Гыйльманов. *Тик моңа кадәр ерып йөргән авызы салынып төшкән дә, күз төпләре чокырланып калган.* Ф.Яхин

**Чокырланып килү** Акрынлап чокырлану. *Әрдәнәнең чокырланып килгән бер уентыгында, дөньядан бихәбәр булып, ярты литрлы шешә ята иде.* Р.Низамиев

**Чокырланып китү** Кинәт яисә бераз чокырлану. *Үзе сүз әйткән саен елмая, елмайган чагында бит урталары чокырланып китә.* Г.Әпсәләмов

**Чокырланып тору** Әле, хәзер чокырланган булу; даими чокырланган хәлдә булу. *Түбәсендә урта җире азрак баткан, чокырланып тора.* К.Насыйри. *Буранбай чокырланып торган киң ияген гармун өстенә куеп, башын кыңгыр сала төшеп, кыска, юан бармакларын гармун телләре өстеннән йөгертеп узды.* Г.Әпсәләмов

**ЧОКЫРЛЫ** *с.* 1) Чокыр(лар)ы булган, чокырланып торган. *Күтәрелә кибән, бер чокырлы җире юк, әйләнәсенең бер бүселгән урыны юк.* Р.Газиз. *Яңгырлы көн иде, авыл башындагы чокырлы юлда машинасы батты.* Н.Гыйматдинова

2) Батынкыланып торган. *Гадәти кара каш, озын керфек, куе коңгырт күзләр, түгәрәк йөз, калын алсу иреннәр, нәни чокырлы ияк.* В.Имамов

3) Эче куыш, тишек (теш тур.). *Чокырлы теш*

**ЧОКЫРЛЫК** *и.* **1.** Чокыр, чокырлы урын. *Кырлар белән кырлар тоташалар, Юллар белән юллар үреләр. Сизелмиләр ярлар, чокырлыклар – Бар төш матур, тигез күренә.* Ф.Яруллин. *Мәхәббәт тупыл үсә чокырлыкта, манарадан биек диярсең...* Н.Гамбәр

**2.** *с. мәгъ.* Чокыр хасил иткән, чокыр булган. *Монда инде көпчәкләрнең җыелган яңгыр суларын күңелле генә чапырдатып узуы да, чокырлык җирләрдә арбаның бер яктан икенче якка янтаеп шыгырдап алулары да аермачык булып ишетелә башлады.* М.Хәсәнов

**ЧОКЫРЛЫ́-ЧАКЫРЛЫ** *с. к.* **чокыр-чакырлы**. *Башта алар чокырлы-чакырлы җирләрдән бардылар.* Г.Әпсәләмов. *Бик азапланып кына йөри, ә разводящийның бөтен эше аяк өстендә – чокырлы-чакырлы сукмакларны аңа көндезен генә түгел, төннәрен дә ничәмә тапкыр әйләнергә туры килә.* Ә.Еники

**ЧОКЫ́Р ТУП** *и.* Җирдә казылган кечкенә чокырларга туп бәреп кертүдән һәм чокырсыз калган кеше «көтү көтү»дән гыйбарәт балалар уены. *Кар китеп, җирләр кипкәч, йөгертмә туп, чокыр туп уйнау...* Ә.Еники. *Койма буендагы яшел йомшак чирәм өстенә җиде-сигез бала чокыр туп уйнап яталар.* Н.Көбәш

**ЧОКЫ́Р ТУПЛЫ** *и. к.* **чокыр туп**. *Аларны салып ташлап, кылган каплаган җылы тау башында лапталы, майладыклы, чокыр туплы --- уеннары оештырдылар.* З.Зәйнуллин

**ЧОКЫРЧА** *и.* 1) Кечкенә чокыр; эчкә керебрәк, батыбрак торган урын. *Аның тирәсендә урнашкан йолдыз чокырчалары исә урындык рәвешендәге Кассиопея йолдызлыгын сурәтлиләр.* А.Тимергалин

2) *к.* **чокырлык**. *Квадрат рәвешендә бераз калкып торган нигез туфра-*

*гын һәм уртадагы баз чокырчасын да чүп үләннәр каплап киткән.* Р.Низами

3) *диал.* Майда йөздереп әзерләнгән ит пәрәмәче. *Чокырча пешерү*

**ЧОКЫ́Р-ЧАКЫР** *җый. и.* 1) Аяк астында, юлда тәгәрмәчләр, яңгыр суы һ.б.ш. тәэсирендә барлыкка килгән эреле-ваклы чокырлар. *Язын-көзен дә, яңгырлы җәйләрдә дә авыр йөк машиналары кызыл балчыклы юлны казып, чокыр-чакырга әйләндереп бетерә.* Г.Ахунов. *Эзләгәннәр: авыл халкы урманның иң ерак, иң аулак шырлыкларын, чокыр-чакырларны, елга-күл тирәләрен айкап чыккан.* А.Гыйләҗев

2) Чокырлардан торган, чокырлар белән тигезсезләнеп беткән җир. *Тегермәндә, каравыл йортында --- сөйләшәләр: яхшы җирләр эләгер микән, әллә кызыл балчык, чокыр-чакыр бирерләр микән?* И.Гази

**ЧОКЫ́Р-ЧАКЫРЛЫ** *с.* 1) Чокырлары күп булган. *Ләке урманында мыж алар, чокыр-чакырлы урман бит, бүре оясы.* А.Гыйләҗев

2) Сикәлтәле (юл һ.б.ш. тур.). *Чокыр-чакырлы урман юлы тарантасны шактый нык чайкый башлагач, Гөлүсә тураебрак утырды.* В.Нуруллин

**ЧОЛАН** *и.* Авыл йортында кеше яши торган бүлмәләр белән болдыр арасындагы, гадәттә кирәк-ярак саклау өчен, ягылмый торган бүлмә. *Әниемнең үтенече буенча шунда ук чоланга чыгып, алдан әзерләп куелган төргәкне алып кердем.* М.Садыйков. *Аның келәтендә һәм чоланында ел буена тозлаган кыяр һәм кәбестә өзелми.* В.Юныс

**ЧОЛГАВЫЧ** *и. сөйл. к.* **чолгау** II. *39 нчы размерлы аягына 43 ле ботинка алып, аягын җиде кат чолгавыч (бишесе – җылы) белән урап чыккан була.* М.Галиев

**ЧОЛГАМ** *и.* Бау, аркан һ.б.ш.ның йөртергә җайлы булсын өчен кат-кат итеп чорналган бәйләме. *Безнең кулда – бау чолгамы, ничәдер багор.* Р.Юныс

**ЧОЛГАНЫШ** *и.* 1) Кемне яки нәрсәне дә булса чолгап, уратып алган тирәлек, билгеле шартлар. *Кушымчаның мәгънәсе дә сүзләр һәм грамматик шәкелләр чолганышында гына ачыла.* Р.Абдуллина. *Ләкин музыка, кеше авыр хисләр чолганышында булганда, аңарда күтәренкелек, илһам урынына бөтенләй башка хисләр уятырга мөмкин.* К.Гыйззәтов

2) Дошман гаскәрләре божрасында калу күренеше, камалыш. *Ул фронтка китте, чолганышта калды, әсирлеккә эләкте, качты, партизаннар отрядында булды.* Г.Әпсәләмов. *Чолганыштан чыгарга омтылып, атакага ыргылалар.* З.Зәйнуллин

**ЧОЛГА́У** I *ф.* 1) Чүпрәк, бау һ.б.ш. нәрсәләр белән чорнау, төрү. *Өлкән кызлары, тукыр өчен, буй сару калыбына җеп чолгый.* М.Галәү. *Заман бае, «эшлекле» бу надан адәм, Чолгау чолгап, алтын башмак кияр иде.* Р.Шәрипов // Урау, бәйләү. *Яулыкны әле башына каплады, әле муенына чолгады, әле иңенә салды.* Ә.Еники. *Ә кармак җебенең кыска өлешен бармагына чолгый, һәм... китә шуннан балык тоту!* Ә.Мушинский

2) Берәр кемне яки нәрсәне уртага алып тирәли урнашу; әйләндереп, уратып алу. *Разведчиклар, связнойны чолгап, сораштыра торган арада, әкертен җил дулкыны әлеге исләрне бирегә үк алып килде.* Г.Әпсәләмов. *Аңа бара торган аллея иң матур фонарьлар белән яктыртылган, зифа буйлы пальмалар, кипарислар сарайны чолгап, бизәп торалар.* А.Гадел // Әйләнә-тирәдә булу, урнашу. *Әмма эшкә өйрәнгәнче, адәм баласы үзен чолгаган дөньядан бик күп нәрсәне сеңдереп, үзләштереп өлгерә ---.* Казан утлары

3) Камау, чолганышка алу. *Шәһәрне икенче кабат Сапожков бандалары чолгады.* А.Хәсәнова. *Иртәгә аларга өстәмә көчләр килеп кушылса, безне чолгап атып бетерәчәкләр ---.* Р.Кадыйров

4) Бар яктан уратып алу. *Карасуны дүрт тарафтан да урман чолгаган ---.* Н.Гыйматдинова

5) Тулысынча каплап алу, томалау; басу. *Сизелмәстән генә артып барган караңгылык бераздан куера, бөтен нәрсәне чолгап, күзнең күрә алачак җирләрен тарайта, кыса килә, ниһаять, тәмам куерып, кара төнгә әйләнә.* Г.Ибраһимов. *Дөньяны ут чолгады.* С.Поварисов. *Шул ук вакытта авылдан читтәрәк урнашкан зиратны да су чолгады.* З.Хәким

6) *күч.* Тулысынча үзенә тарту, биләп алу (фикер, хис һ.б.ш. тур.). *Күңелем басылган кебек булып тагы яттым, тагы ямьсез фикерләр мине чолгады, тагы егладым, тагы тордым ---.* Г.Исхакый. *Күкрәкне авыр бер уй чолгый.* Һ.Такташ

7) *күч.* Кемнеңдер янында булу, аралашу, даирәсенә керү. *Шул вакытта аны чолгап алган кешеләрдән бик күбесен икешәр генә сүзле җөмләләр белән, бәгъзан көлке вә бәгъзан ачы сурәттә тәгъриф итте.* Ф.Әмирхан

8) *күч.* Җәелү, киң таралыш алу. *--- чөнки Җир шарын чолгаган бу чиргә әле дәва табылмаган.* А.Гыйләҗев. *Битарафлык җәмгыятьне чолгады.* Өмет

**Чолгап алу** Бөтенләй, һәр тарафтан чолгау. *Мәйданны, күл тирәсен төзү материаллары чолгап алган.* А.Алиш. *Үзән өстеннән гүя күк качты – һәммә җирне яшькелт-алсу ут чолгап алды.* А.Толстой

**Чолгап бетерү** Ахырга кадәр чолгау; бик нык чолгау. *Аның ташкыны язмышларны, чолгап бетереп, дәрьяга ташлый.* Н.Гыйматдинова

**Чолгап калу** Чолгарга өлгерү. *Такталачык җанын Сагыш чолгап кала.* Л.Шәех

**Чолгап кую** Чолганган хәлгә китерү. *Без аның кияүдәме, юкмы икәнен шуннан беләбез: баш өстенә, чәченә генә булса да, яулыгын чолгап куя.* Безнең гәҗит

**Чолгап тору** Әле, хәзер чолгау. *Кызыл Армиянең 1919 елгы җәйге омтылышын башлар алдыннан, М.Фрунзе шәхсән аны, Оренбургны чолгап торган дошманның төп көчләрен беркадәр ачыклау кебек четерекле бурычны үтәү өчен, Самарадан озатып калган.* Л.Хәмидуллин

**Чолгый бару** Торган саен күбрәк чолгау. *Һәр сулышы саен мәхәббәт тетеннәре чыга, тәнен генә түгел, бар дөньялыкны чолгый бара иде.* Ф.Яхин

**Чолгый башлау** Чолгарга тотыну. *Җир өстеннән бик аз гына караңгылык күтәрелеп, һәммә нәрсәне чолгый башлый.* Г.Ибраһимов. *Шулчак Сәкинә әбинең кызгану хисләре белән янган күзләрен ачу катыш көнләшү ялкыны чолгый башлады.* Безнең гәҗит

**ЧОЛГА́У** II *и.* 1) Кайбер аяк киемнәрен кигәндә аякка урала торган озынрак тыгыз тукыма кисәге; ыштыр. *Шуңа бер пар чиккән өстәл эскәтере, дүрт намазлык, аннан соң берничә пар аяк чолгаулары кирәк буласы иде.* Г.Камал. *Учак янындагы казыкларга эленгән чолгаулар, чабаталар, үкчәләренә кара ямау салынган ак йон оекбашлар парланып торалар.* А.Гыйләҗев

2) Берәр нәрсәне уратып торган, киертеп куелган махсус материалдан эшләнгән җайланма. *Газ баллонын тоташтыру өчен металл чолгавы булган шланг*

**ЧОЛГАУЛЫ** *с.* Чолгавы булган; чолгау белән киелгән; чолгау киертелгән. *Башында кызыл йолдызлы шлем,*

*өстендә солдат шинеле, аякларында чолгаулы ботинка.* Р.Низами. *Ә газ баллоннарын палатка эченә урнаштырырга ярамый, алар плитәләргә металл чолгаулы махсус шланг белән тоташтырылырга тиеш.* Байрак

**ЧОЛГАУЛЫК** *с.* **1.** Чолгау өчен билгеләнгән, чолгауга ярый торган. *Чолгаулык тукыма*

**2.** *и. мәгъ.* Чолгауга ярый торган тукыма. *Мәрьям Вахит абзасына кирәк булган чолгаулык, тастымаллык кебек ак киндерләрне, аңа хаслап, күбрәк сукты.* М.Гафури

**ЧОЛГАУЧЫ** *с. иск. мат.* Камаучы (фигура)

**ЧОЛГЫЙ** *и. диал. к.* **чылгый**. *Мыек чолгыйлары матур итеп кыскартылган, чиста кырылган.* М.Хәсәнов. *Тик беләк мускуллары гына чүлмәкчүлмәк күпереп ала, чәченең бөдрә чолгыйлары дерелдәп-дерелдәп куйгалый.* Ә.Галиев. *Барысы да торып, Анифә апа эшкә киткән, Мирза абый көзге алдында кара чолгый мыегын төзәтеп утыра иде.* Х.Сарьян

**ЧОЛГЫЙЛАНУ** *ф. диал. к.* **чылгыйлану**

**Чолгыйланып тору** Әле чолгыйлану; чолгыйланган хәлдә булу. *Калын, таза муенлы булганга җитү сакалы, чолгыйланып торган кырпак мыегы бик килешеп тора үзенә.* Ә.Галиев

**ЧОЛЫК** *и.* Үсеп утырган агач куышында урнашкан кыргый бал кортлары умартасы. *Алар балык тота, ауга йөрегән була, чолыклары бар, шундыйрак кәсепләре белән җан асрыйлар.* З.Мурсиев. *XV–XVI гасырларда мордваларда чолык умартачылыгын бүкән умартачылыгы алыштыра.* Б.Хәмидуллин

**ЧОЛЫКЧЫ** *и.* Чолыкчылык белән шөгыльләнүче, кыргый бал кортларының балын җыючы. *Чолыкчылар, үсеп утырган агачларда махсус куыш ясап, кыргый бал кортларын ияләштерә торган булганнар.* А.Тимергалин. *Кече чолыкчы агачтан төшүгә, каршысына балалы аю килеп чыга.* Безнең гәҗит

**ЧОЛЫКЧЫЛЫК** *и.* Урмандагы кыргый бал кортларының балын җыю һәм аларны караудан гыйбарәт умартачылык. *Шулай ук җыючылык һәм чолыкчылык, ягъни җиләк-җимеш һәм урман умарталары балын җыю да халык кулланышында булган.* Б.Хәмидуллин. *Бөрҗән – Русиядәге һәм Европадагы чолыкчылык сакланып калган бердәнбер төбәк.* Кызыл таң

**ЧОМБУ́РИ** *и. груз.* Грузиннарның грушасыман корпуслы дүрт кыллы музыка коралы; *русчасы*: **чонгури**. *Грузин улы Лепеберидзе чомбуриен кулына ала.* Ә.Маликов

**ЧОМБЫРАК** *и. диал.* Бик ерак җир, ара. *Бик тә ерак-ерак җирләрне, афәтле дә һәм кайбер төштә рәхәтле дә чомбыракны – араны үтеп, җитмеш яшен тутырган бу көннәрдә Гурий дәдәйдә яшьлегендәгечә көч-куәт бар, иҗатын туктаусыз бөтәйтерлек электәгечә кодрәт-гайрәт аңарда.* М.Хуҗин

**ЧОНТАЙ** *и. монг. иск.* Кечкенә күн капчык, янчык

**ЧОНТЫК** *с. диал.* **1.** 1) Киселгән койрыклы; кыска койрыклы (хайван тур.). *Туктале, ул бит мине чонтык эт итеп күрергә теләгән генә, ә күрүен бозау итеп, аның да сараягы итеп күргән була түгелме соң?* М.Хуҗин

2) Кулы яисә аягы җитлекмәгән, кыска калган. *Сәмәркандта утырган Аягы чонтык Шаһ Тимер Әмир Бырлас син булсаң ---.* Дастан. *Энем тумыштан ук менә чонтык булып калган.* В.Имамов

3) Киселгән; кыска, өтек (берәр әгъза тур.). *Аргамагы да гаебен төзәтергә ашыкты: чонтык койрыгын тырпайтты, һөҗүмгә ыргылды.* М.Әмирханов

**2.** *и мәгъ.* Кулы яисә аягы җитлекмәгән, кыска калган кеше. *Ул чонтыкны шул хакта кисәтергә дә онытма.* В.Имамов

**ЧОҢГЫЛ** *и.* 1) Сулыктагы бик тирән чокыр, бик тирән урын. *Әледән-әле алда бөтерелеп торган чоңгыллар, су астыннан калкып чыккан ташлар очрый иде.* Г.Әпсәләмов. *Безнең өлеш янындагы Ажги амбары дигәннәре – тегермән буасында текә ярлы тирән бер чоңгыл гына ул.* Г.Бәширов

2) *күч.* Иге-чиге булмаган, күплеге, киенлыгы белән куркытып торган нәрсә. *Заман проблемалары чоңгылында киләчәккә юл ярган, тормышта күп киенлыкларны җиңеп үз урыннарын эзләгән яшьләр образларына Ф.Әмирханның «Тигезсезләр» (1914) драмасы, «Хәят» (1912) повесте һәм «Урталыкта» (1912) романнарында да зур урын бирелә.* М.Хәсәнов. --- *ниндидер бер хәлиткеч карарга килер алдыннан әнисе менә шулай тере сын сыман катып кала да тирән уй чоңгылына чума.* А.Хәлим

3) *күч.* Кешене үзенә бөтереп, тартып алган нәрсә. *Айдар исә ул арада бизнес дигән чоңгылда әйләнә башлый: каяндыр ала, каядыр сата – ничек булса да акча эшләү юлларын таба.* Кызыл таң

4) *күч.* Яшәү өчен авыр шартлар, матди кыенлык, юксыллык. *Анда торып, шул чоңгылдан бер генә кешене тартып чыгарсак та олы савап булыр.* Безнең гәҗит

5) *күч.* Рухи түбәнлек, әдәпсезлек

◊ **Чоңгылга төшү** Юкка чыгу, бетү. *Мәмләкәттәге һөнәрчелек белән сәүдәгәрлек чоңгылга төшеп бара.* В.Имамов

**ЧОҢГЫЛТ** *иярт.* Берәр авыр нәрсә кисәк суга төшкәндә ишетелгән өзек тавышны белдерә

**ЧОҢГЫ́ЛТ ИТҮ** *ф.* Чоңгылт иткән тавыш чыгару. *Без аткан балчык кисәге чоңгылт итеп суга барып төшүгә, берсен берсе куып китә бөҗралар, китә бөҗралар!* Г.Бәширов

**ЧОҢГЫ́Л-ЧОҢГЫЛ** *с.* Чокыр-чакырлы, сикәлтәле. *Юллар монда чоңгыл-чоңгыл булып казылып беткән иде.* Г.Ахунов

**ЧОР** *и.* 1) Гомуми процессның бер өлеше, узган вакыт аралыгы. *Малайлыкның иң тәмле чоры бу.* А.Хәсәнов. *Ул Атлантида яшәгән чорда Мадейра атаулары Пиреней ярымутравы белән тоташкан булган дип уйлый.* А.Тимергалин. *Табигатьнең чәчәкләргә күмелгән чоры бу.* А.Нәҗми

2) Җәмгыять, халык үсешендәге үзенә генә хас үзенчәлекләре булган, аерым вакыйгаларны үз эченә алган зур гына вакыт аралыгы; дәвер. *Бик ихтимал, Казан ханлыгы чорында да атлар белән шунда сату иткәннәрдер.* А.Тимергалин. *Үзгәртеп корулар чоры башлангач, берара, иҗат методлары белән шөгыльләнү – кирәксез эш, дигән сымак фикерләр яңгырады.* А.Әхмәдуллин

3) Үсешнең, эшчәнлекнең бер стадиясе, аерым бер моменты. *Бу яктан караганда, соңгы ун ел милләтебез өчен шатлык чоры булды, әдәбиятыбыз өчен бәйрәм булды.* А.Тимергалин. *Баштагы чорларда миннән көлүчеләр дә, шаяртучылар да күп булды.* А.Хәсәнов

4) *сөйл.* Хәзерге заман, әйтелгән, сөйләнгән моментка туры килгән вакыт. *Әсәр бик түбән сыйфатлы һәм чорга җавап бирми.* М.Җәлил

5) *геол.* Системаны тәшкил итә торган утырмаларның барлыкка килгән вакыт аралыгы, эраның бер өлеше; заман. *Бу эра үзе генә дә берничә чорга бүленеп, пермь чоры, ташкүмер чоры, девон чоры, силур чоры, кембрий чоры дигән исемнәр белән йөртелә икән.* Ш.Бикчурин

**ЧОРДАШ** *и.* Кем белән дә булса бер вакытта яшәгән яки яшәүче кеше; яшьтәш. *Минем өчен Лена гына, класташым, сердәшем, чордашым Лена гына мөһим булган.* А.Гыйләҗев. *Син бездән әллә ни олы түгел, кистереп әйтсәң, чордаш дияргә дә була.* В.Имамов

**ЧОРЛАП** I *рәв.* Чорларга бүлеп; аерым чорына карап, шуңа карата. *Р.Ганиева – татар әдәбиятын буйданбуйга да, төрле чорлап та укыткан зат.* Х.Миңнегулов

**ЧОРЛАП** II *рәв. диал.* Шарлап, ургылып, бик көчле агым булып. *Аларның башларыннан һәм маңгайларыннан чорлап кан агып төшә.* М.Гафури

**ЧОРМА** *и.* Бинаның түшәме белән түбәсе арасындагы урыны. *Ә мунча чормасында нечкә тавыш белән песи балалары мияуларга кереште.* А.Хәсәнов. *Дөбер-шатыр кемдер чормага менеп килә иде.* Аманулла

**ЧОРМАВЫК** *и. бот.* **1.** 1) Аралиячәләр семьялыгыннан берәр нәрсәгә чорналып, үрмәләп үсә торган саргылт яшел чәчәкле мәңгеяшел лиана; *русчасы:* **плющ**. *Шунда ук тәрәзә араларында ямь-яшел булып үрмәле гөлләр, чормавыклар үсә.* М.Хәсәнов. *Тереклек тамыры, кытай лимоннигы, ләүзия (марал тамыры), сөйкемле куак (заманиха), чормавык (аралия), дүләнә, кыргый борыч (элеутерококк) матдәләр алмашын көчәйтә, тынычландыра, хәл кертә, кәефне күтәрә.* Мәдәни җомга

2) *к.* **кычыткан ефәге**

**2.** *с. мәгъ.* Чорнала торган; чорналган, ябыша торган. *Нуриман юлдашының саташулы-йокылы күзләренә карады, чуалган чормавык бауларын төзәткәләде һәм, бил тиңентен кар ярып, түбәнгә төшүен дәвам итте.* Ә.Мушинский

**ЧОРМАВЫ́КЧАЛАР** *и. бот. иск.* Кычыткан ефәге төрләре кергән паразит үсемлекләр семьялыгы. *Чормавыкчалар семьялыгына кергән бу паразит чүп үләне басуларда уңышның күләмен һәм сыйфатын нык киметә, азыклар аша терлек организмына эләгеп, аларда агуланулар китереп чыгарырга мөмкин.* Саба таңнары

**ЧОРМАЛУ** *ф. диал. к.* **чорналу**. *Кызлар бөтен тарафыннан вак кына нарат урманы берлә чормалган бер аланның читенә туктадылар.* Г.Исхакый

**Чормалып яту** Озак вакытлар чормалу; әле хәзер чормалу. *Бәлки бабаларымыз гадәтен югалтмыйк дип, кирәкмәс гадәтләремезгә чормалып яттык.* Г.Исхакый

**ЧОРМА́У** *ф. диал. к.* **чорнау**. *Шәйхулланың дүрт баласы: «Әти, әти!» – дип, аны тишенергә бирмәенчә чормап алдылар.* Г.Исхакый. *Икмәкне чүпрәккә төреп, бау белән кат-кат бәйләде һәм, бау очын йомгак итеп чормап, сакчы күрмәгәндә егеткә ыргытты.* Идел

**Чормап алу** Тиз генә чормау. *Аларны кышкы баздан кояшка чыгарып куйган ач бал кортлары чормап алган!* А.Хәлим

**ЧОРНАВЫЧ** *и. махс.* Җепне, тимерчыбыкны һ.б.ш. чорнау өчен кулланыла торган җайланма. *Ә тасма бер чорнавычтан икенчесенә савыла да савыла...* Б.Камалов

**ЧОРНАЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **чорнау** (*1–3 мәгъ.*). *Чүпрәккә чорналган, каны саркып торган бурзай йомарланып тын гына ята иде.* А.Вергазов. *Икесенең дә башлары, куллары бинтка чорналган.* Л.Лерон

2) Һәр яктан каплап алу, урау. *Кар ява, ява, чорнала, Шәл булып өскә төшә.* К.Булатова

**Чорнала бару** Торган саен күбрәк чорналу. *Кош, кискен хәрәкәтләр ясаган саен, ятьмәгә ныграк кына чорнала барачак.* Безнең гәҗит

**Чорнала башлау** Чорналырга тотыну. *Караңгылыкка чорнала башлаган озын тар коридорда ник бер бала тавышы ишетелсен.* Кызыл таң

**Чорналып бетү** Тәмам чорналу, бик нык чорналу. *Агачлар, куаклар бер-берсенә бездәге эт эчәгесенәме, әллә ниткән үсемлекләр белән уралган, чорналып беткән.* Н.Әхмәдиев. *Казан үзенең Печән базары, Болагы, Балык базары белән, аннан бигрәк тә эшсез, имансыз, фасикъ яшьләре, баштанаяк мәгънәсез интригалар эчендә чорналып беткән «хадиме милләтләре» белән мине гаҗәп туйдырды.* М.Хәсәнов

**Чорналып калу** Ахырда чорналган булу. *Хәтер йомгагына шундый бер сөйләшү чорналып калган.* Т.Галиуллин

**ЧОРНАМ** *и.* Берәр тигез озынча нәрсәгә яки үзе генә йомгак итеп чорналган яки чорналырга тиешле җеп, тасма һ.б.ш. бәйләме. *Бер чорнам тасма*

**ЧОРНА́У** I *ф.* 1) Җеп, тукыма, чүпрәк кисәге һ.б.ш.ны нәрсәгә дә булса урау. *Муенына калын мамык шарф чорнаган, кыршылган язгы пальтолы, аксыл чәчле бер абзый – язучы икән.* М.Мәһдиев. *Киләпле буйлык җепләрне тагын йомгакка чорнадылар.* Д.Каюмова

2) Берәр нәрсә эченә салып төрү, төргәк, төен итеп ясау. *Гамил яңадан шприцны яулыкка чорнап кесәсенә тыккач: «Менә шушы шприц белән Рәкыйп үтерелгән иде, анда хәзер синең бармак эзләрең» [– диде].* Р.Сәгъди // *сөйл.* Төреп ясау. *Биктимер (тәмәке чорный): Безнең колхозның кайсыдыр бер җирендә елан бар, Галимә.* А.Алиш. *Бармак юанлыгында итеп махра чорный да, коридорга чыгып, шуны көйрәтә.* А.Расих

3) *сөйл.* Берәр кешене әйләндереп басу, тирәсенә туплану. *Тирә-ягымны да тышлары бик артык ялтырамый торган чабаталы адәмнәр – мужиклар чорнар.* Г.Ибраһимов // Үзенең эченә алу, әйләнә-тирәдә булу. *Моңа әтинең тырышлыгы һәм мине чорнаган мохитнең тәэсире чиксез булды.* А.Хәсәнов

4) Бар яктан каплап алу. *Ул ни яна шундый шомлы булып, Җирне ялкынтөтен чорнаган?* И.Юзеев. *Кинәт җирне сыек караңгылык чорный, яшен яшьнәп, күк күкри.* М.Кәбиров

5) *күч.* Нәрсәне яки кемне дә булса берәр төрле халәт, хис биләп алу, күмү. *Бер ерактан, бер якыннан мине Сагышларга нигә чорныйсың?..* Л.Шакирҗанова. *Бәлки, кирәге дә юктыр инде Үткәннәрне искә алырга. Хатирәләр белән аңны чорнап, Яраларга тозлар салырга.* К.Фатыйхова-Бәдретдинова

**Чорнап алу** Тиз генә чорнау; тулысынча, тоташ чорнау. *Шул вакытта көтмәгәндә умарта сакчылары – бал кортлары, шпагаларын әзер тотып, аюны чорнап алалар.* А.Гадел. *Берәр көнне, көтмәгәндә генә килеп чыгып, бөтен урманны чорнап алып, облава ясарлар.* А.Хәсәнов

**Чорнап бетерү** Ахырга кадәр чорнау, беткәнче чорнау

**Чорнап кую** Алдан ук чорнау; чорнап калдыру. *Иренең ул чорнап куйган мәкерле йомгакны сүтә башламавына аның күңеле кителде.* А.Вергазов. *Әллә каян гына бау кисәге тартып чыгарды, атлар иясенең кулларын чорнап куйды.* В.Имамов

**Чорнап ташлау** Бик тиз арада, аннан-моннан чорнау. --- *монитордагы дәү сейфка якынлашканда гына, әллә кайдан зур үрмәкүч килеп чыгып, аның өстенә пәрәвез ыргытты һәм сейфны шуңа чорнап та ташлады.* З.Мурсиев

**Чорнап тору** Даими чорнау; әле, хәзер чорнау. *Шулай чорнап тора безне*

*җәһаләт, Шулай: «Тырп итмә!» – ди безгә сәфаләт*. Г.Тукай

**Чорнап чыгу** Һәрберсен аерым-аерым чорнау

**Чорный бару** Бер-бер артлы чорнау, булган берсен чорнау. *Юк бит, юк, берсе артыннан берсе, үзәкне тагы да өзә торганнары чорный барды*. Г.Галиева. *Безнең язмышларны «язып» алган су. Вакыт чорный барган...* Х.Әюп

**Чорный башлау** Чорнарга тотыну. *Төргәкләрне икешәр-икешәр итеп, балтырларының ике ягына куеп, аякчу белән чорный башлый*. Г.Камал. --- *кояштай күз чагылдыргыч алтын чәчле малай, куркуыннан, минекеннән дә озын чыбыркысын беләгенә чорный башлады*. К.Кәримов

**Чорный тору** Туктаусыз чорнау; әлегә чорнау. *Тизлеген чамасыз арттырган тарих тәгәрмәче көннәрне, атналарны ашыгып-кабаланып йомгакка чорный торды...* А.Гыйләҗев

**ЧОРНА́У** II *и*. 1) Урау, төрү, урап алу күренеше. *Фетнәчеләр ягыннан берәрсе очына ут эленгән ук очырса, крепостьны ялкын чорнау куркынычы туа*. В.Имамов

2) Чорналган җеп, тукыма һ.б.ш. нәрсәләр кисәге. *Күләгә булганга үлән заты үсмәгән кара җирдә бер чорнау юан бау ята иде!* А.Тимергалин

3) *физ*. Чорналган үткәргеч тимерчыбыктан гыйбарәт деталь. *Трансформаторның беренчел чорнавы тиз эрүчән саклавыч аша электр челтәренә тоташа*

**ЧОРСЫЗ** *с*. **1.** 1) *сөйл*. Артык шук, артык шаян. *Бераз чорсызрак, мактанчыграк, кылтыграк булса да, ул Җәбирне үз итә, якын күрә*. Н.Фәттах. *Гомергә чорсыз булды шушы Фәгыйлә, исәнлек-саулык сорашмас, теленә килгән беренче сүзен тәгәрәтеп төшерергә ашыгыр*. А.Әхмәтгалиева

2) *диал*. Тәрбиясез, тәртипсез, әдәпсез. *Тик менә Кәрим абый салырга ярата, аннары балалары гына чорсызрак: сугышалар, елыйлар, кычкыралар*. Н.Фәттах

3) *диал*. Көйсез. *Бригадирның аты чорсыз икән, камыт салдырып киерткәндә баш бирмичә алҗытты*. М.Мәһдиев

**2.** *рәв. мәгъ*. Көйсез итеп; тәртипсез, әдәпсез рәвештә. *– Аның миңа бер зыяны да тими, – дидем мин карчыкка, күңелемнән исә: «Бик чорсыз өйрәткәннәр балаларын», – дип уйлап куйдым*. Н.Фәттах. *Нишләде ул, я, ник чорсыз кыланды, үзен тыймады!* Р.Мулланурова

**ЧОРСЫЗЛАНУ** *ф*. 1) *сөйл*. Шаяру, шуклану

2) *диал*. Көйсезләнү, үзсүзләнү; әдәпсез кылану. *Көйсезләнә, чорсызлана, аяк тибеп еларга тотына*. М.Әмирханов. *– Чорсызланма, кызым, – диде Дәүләтгәрәй абзый Дездемонага*. Н.Фәттах

**Чорсызланып тору** Гел чорсызлану; әле, хәзер чорсызлану. *Элеккеге --- Сәгыйдә урынына --- моңаеп, чорсызланып тора торган, ярым җанлы гына бер Сәгыйдә калган иде*. Ш.Камал

**ЧОС** *с. диал*. Булдыклы, өлгер, маһир, һәвәс. *Шуның белән бергә ул да бик кыю, гайрәтле һәм сугышырга да бик чос малай иде*. Ә.Еники. *Хатын-кыз бит – чагыштыру юлы белән ялгыш нәтиҗәләр ясарга чос кавем*. Р.Зәйдулла

**ЧОСЛЫК** *и*. Булдыклылык, уңганлык. *Күпме чослык, өлгерлек, тизлек кирәк бу уенда!* Ә.Еники. *Тегесе «прихватизация» чорында чослык күрсәткән икән – шулай нык баеп калган*. Кызыл таң

**ЧОШ** I *и. диал. к*. **шеш** II. *Чөнки урманлы якларда колгалардан, чошлардан өелгән конуссыман өйләр киң таралган булган*. Р.Әхмәтьянов

**ЧОШ** II *ы*. Берәр кешене үртәү максаты белән, нәрсәне дә булса бирмәү, эшләмәүне белдереп, көтелгәннең киресе булуын ассызыклап әйтелә; шиш, пычагым. *Без ул дәресләрдә җөмлә тикшереп утыра дип беләсезме? Булыр... Чош!* Ф.Латыйфи. *Кырык бер ел элек чош «әткәм белән әнкәмә» заказать иткән булыр идем үзен!* Р.Гаязетдин

**ЧОШ** III *иярт*. Печән чапканда бер тапкыр селтәнеп алганда һ.б.ш. очракларда ишетелгән тавышны белдерә. *Ирләр, торналардай тезелешеп, куетыгыз үләнне чош та чош чабалар ---*. Ә.Еники

**ЧО́Ш ИТҮ** *ф*. Чош сыман тавыш чыгару

**ЧО́Ш-ПОШ** *иярт*. Кайбер механизмнар, моторлар эшләгәндә ишетелгән тавышны белдерә

**ЧО́Ш-ПОШ ИТҮ** *ф*. Чош-пош сыман тавыш чыгару. *Моторның бер җире аксады да, машина чош-пош итә башлады*. М.Шәрифуллин

**ЧОШТЫРДА́У** *ф*. Чоштыр-чоштыр килгән тавышлар чыгару. *Ишетәм, аргта нидер чоштырдый*. А.Гыйләҗев. *Коры ботаклар да шартлап сынмый, кипкән яфраклар да чоштырдамый*. Р.Батулла

**ЧОШТЫ́Р-ЧОШТЫР** *иярт*. Үлән ерып барганда, коры үләнне кузгатканда, өстенә басканда, җиңел, әмма тыгыз тукымадан эшләнгән әйберләр хәрәкәтләнгәндә, тиеп киткәндә чыккан тавышларны белдерә. *Гади генә киенгән егетләр һәм кызлар шунда ук дәртләнеп, чоштыр-чоштыр әйләнергә дә тотыналар...* Ә.Еники

**ЧОШТЫ́Р-ЧОШТЫР ИТҮ** *ф. к*. **чоштырдау**

**ЧӨГӘ** *и*. Мәрсинчәләр семьялыгыннан сырты кабырчыклы, кара уылдыклы, төче сулыкларда яши торган кыйммәтле балык; *русчасы:* **стерлядь**. *Татарстан балыкчыларына, елга, күл буйларында укмашкан әртил, бригадаларга ныклы боерык китте: әгәр ятьмәләргә кырпы, эре чөгә, мәрсиннәр эләгә икән, һәммәсе тимерьюлчылар карамагына тапшырылырга тиеш*. А.Гыйләҗев. *Ул җәен дисеңме, ул чөгә дисеңме, ул чуртан дисеңме – чутыхисабы юк иде...* Р.Батулла

◊ **Чөгә балыгы кебек** Ябык; бик ябык кеше

**ЧӨГЕНДЕР** *и. фар*. 1) Алабутачалар семьялыгыннан тамыры ашамлык, терлек азыгы һәм аерым төре шикәр җитештерү өчен игелә торган икееллык яшелчә үсемлек. *Мәчтүрә минем – уңган хатын. Балалар ишле булгач, ел саен дүрт-биш гектар чөгендер үстереп бирә*. Н.Әхмәдиев. *Чөгендер йолкып маташкан бу малай кисәге мине кем беләндер бутый иде бугай, якын танышына эндәшкәндәй, яктырып сәлам бирде*. А.Әхмәтгалиева

2) Шул үсемлекнең ашамлык яки терлек азыгы итеп кулланыла һәм шикәр ясауга китә торган йомры тамыры. *Бәрәңге, чөгендер, кишерне казып алып җилдә киптерделәр, базларга, идән асларына кертеп салдылар*. М.Галәү. *Хәтәр саллы гына ике капчык кишер, кызыл чөгендер, шалкан белән тулды*. В.Имамов

3) *сөйл*. Шул үсемлек утыртылган җир, бакча. *Сәрбиназ шуларны белә, ә мин һаман чөгендер чүбен йолкыйм!..* А.Гыйләҗев. *Чөгендер буразнасыннан тәпи атлап киткәнмен, чөгендер арасында телем ачылган*. Аманулла

◊ **Чөгендер кебек (шикелле)** Кыпкызыл булып. *Бу сүзләрне тешләрен кысып, ачулангандай әйтергә тырышса да, Миңнисаның бит алмалары егетне күргәч чиксез шат икәнлеген сатып тора – чөгендер кебек кызарып чыкты*. А.Фәләх. *Каен яфраклары ябышкан аяклары да, чөгендер шикелле кызарган йөзе дә*

*аның әле генә мунчадан чыкканлыгын кычкырып тора иде.* В.Имамов. **Чөгендер төяү** Кызарып чыгу; оялу (кеше тур.)

**ЧӨГЕНДЕ́РАЛГЫЧ** *и. а.х.* **1.** Чөгендернең тамырын казып чыгара торган авыл хуҗалыгы машинасы; *русчасы:* **свеклоуборщик**

**2.** *с. мәгъ.* Чөгендер алу өчен хезмәт итә торган. *Техникага җансыз тимер итеп кенә караганлыктан, бу комбайнның 7868 сум 19 тиен торуын белгәнлектән, Василий чөгендералгыч җайланманы бик кадерләп йөртте, аны тагын эшләтәчәк!* Х.Бәдретдинов. *Чөгендералгыч сатып алу*

**ЧӨГЕНДЕ́РКАЗЫГЫЧ** *и. а.х. к.* **чөгендералгыч**. *Яңа чөгендерказыгыч*

**ЧӨГЕНДЕ́РТУРАГЫЧ** *и. а.х.* Шикәр җитештерүдә чөгендерне ваклап турау җайланмасы; *русчасы:* **свеклорезка**. *Малларга азык әзерләү өчен чөгендертурагычы, фураж оны тарту җайланмалары бар.* Маяк

**ЧӨГЕНДЕРЧЕ** *и.* Чөгендер үстерүче, чөгендер үстерү белән шөгыльләнүче авыл хуҗалыгы белгече. *Ә менә Фәйзулла карт эш таба алмады, чөгендерче Нәгыймә, пенсиягә авылда чыгарга өлгермәгәнлектән, яңа елга кадәр район үзәге белән кала арасын таптады.* Ә.Әминев. *Әтисе – колхозда алдынгы тракторчы, әнисе Рәшидә апа уңган чөгендерче була.* Кызыл таң

**ЧӨГЕНДЕРЧЕЛЕК** *и. а.х.* Авыл хуҗалыгының чөгендер үстерү эше белән шөгыльләнә торган тармагы. *Аннан Ярмөхәммәтнең озак еллар иске машинада эшләп, тракторга утыруы, аның чөгендерчелектәге уңышларына да кереп чыктылар.* Р.Батулла. *Бүгенге көндә хуҗалык, нигездә, чөгендерчелек тармагыннан кергән табыш исәбенә яши.* Кызыл таң

**ЧӨЕЛДЕРЕК** *и.* Камыт агачларын тарттырып бәйли торган (гадәттә каештан ясалган) бау. *Камытны чөелдерек белән тарттырып бәйләп куялар.* А.Тимергалин. *Сәетҗан абый калтыранган куллары белән чөелдерек бавын чишә алмый азаплана иде.* М.Маликова

**ЧӨЕЛМӘ** *с.* Беркадәр өскә карап тора торган һәм кыска (борын тур.). *Аның чөелмә борыны өстенә тир бәреп чыкты.* Г.Сабитов

**ЧӨЕЛҮ** *ф. төш. юн. к.* **чөю**. *Кинәт күккә ракеталар чөелде.* Г.Әпсәләмов. *Өскә түбәтәйләр очты, букчалар чөелде.* Р.Батулла

**Чөелә башлау** Чөелергә тотыну

**Чөелеп бетү** Тәмам чөелү. *Әби патша тарантасы өчен салынган ташлы юлда дүрт сәгать буе дыңгырдаткач, пассажирлар чөелеп бетте.* К.Кәримов

**Чөелеп китү** Кинәт кенә чөелү. *Мөхәррәмов болай ук чөелеп китәргә уйламаган иде, әмма күңелләргә үтеп кергән уенның тәэсире сәбәбеннәндер, ул да үзенең репертуарын башкарырга керешге.* Ф.Яхин

**Чөелеп тору** Чөелгән хәлдә булу. *Почык борын гына элеккечә, мине үртәп, өскә чөелеп тора.* М.Галиев

**ЧӨЕНКЕ** *с.* Кыска һәм очы беркадәр күтәрелеп торган, чөелмә (борын тур.). *Ә төскә-йөзгә болайрак: уртача буйлы, озын да түгел, карсак та түгел, куе кашлы һәм зәп-зәңгәр күзле, чөенке борынлы, сакалсыз, әмма артык озын булмаган мыегы бар.* М.Хәбибуллин. *Габделнур, текәлеп карап, аның йөзен хәтерендә калдырды: бетчәле бит, очлы чөенке борын, сары чәч.* Р.Кәрами

**ЧӨЕП** *рәв.* Почмакларын артка кайтарып (башка яулык бәйләү тур.). *Син һаман шушы яулыгыңны чөеп бәйләп, тыкрыктан суга төшәсең кебек...* А.Гыйләҗев. *Бүлмәдә яулыгын баш артына чөеп бәйләгән яшь кенә ят хатын да бар.* А.Әхмәтгалиева

**ЧӨЕРҮ** *ф.* 1) Ыргыту, югарыга ташлау; чөю

2) Югарыга күтәрү, өскә таба сузу. *Ислам борынына үрелә, буе җитми, Ислам башын артка чөерә.* А.Гадел. *Ә мин бу егет яныннан алай борын чөереп кенә узып китә алмадым.* А.Хәсәнов

3) Читкә бору, читкә алу (йөзне һ.б.). *[Бала] Судан битен чөерде.* Татарстан яшьләре

4) *күч.* Кайтару, башка якка җибәрү, бору. *Колагыма ишетелгән бала тавышы мине фикеремнән чөерде.* Г.Исхакый. *Күкрәкләрен киереп, Тәннәрдәге пулярны Көпшәләргә чөереп!* Г.Әпсәләмов

**ЧӨЙ** I *и.* **1.** 1) Берәр нәрсәне ныгыту, томалау яки яру өчен, бер башы очлы яссы агач яисә тимер кисәге. *Тәуфикъ яннарында аунап яткан бүрәнә йөзенә балтасын чабып ярык ясаган да чөй каккан.* Г.Гыйльманов

2) Күчәр башларындагы махсус тишекләргә тәгәрмәчләр чыкмасын өчен кертеп куела торган үзәк; чәкүшкә. *Кадрәк янгарак тайпылды, өне китәрдәй булып, тимер күчәрләрнең көянтәдәй алга бөгелгәнен күрде, киерелгән тәҗе башлары күчәр чөйләрен суырып чыгарды.* Ә.Гаффар

3) Кием-салым һ.б.ш. элеп кую өчен кая да булса кагып куелган кадак яки агач таякчык. *Айтуганов кулындагы кожанын ишек янындагы чөйгә элеп куя.* Т.Гыйззәт. *Мин, чемоданымны койка астына куеп, плащымны баш очындагы чөйгә элдем дә каютадан чыктым.* Ә.Еники. *Стенага каккан озын имән чөйләрдә сары каешлы камыт, иске ыңгырчак һәм бик күптәнге бер ияр эленеп тора.* А.Тимергалин

**2.** *с. мәгъ.* Очлаеп торган. *Ап-ак чөй сакаллы Хәлиулла бабай һәм аның гомер юлдашы Шәмгөлҗәннан әби башта аптырап калдылар.* Ш.Ракипов. *Платон Платонович Захарчук Нәҗипнең кафедра мөдире иде. Озын буйлы, чөй сакаллы какча кеше, эре бөртекле кашлары күз читенә таба ишелеп төшкән.* А.Гыйләҗев

◊ **Чөе бушау** Җебү, мәлҗерәү. *Чигә чөе бушаган Иннокентий йөрәген тотып сыгылып төште.* З.Мәхмүди. **Чөй кагу** Юмалау, мактап-хурлап эшләтү, алдап күндерү. *Председатель үзе дәшми, кирәк җиргә чөй кагып кына җибәрә.* Г.Толымбай. **Чөй өстенә тукмак** Берәр кыенлык, мәшәкать өстенә икенчесе килеп чыгу, өстәлү турында әйтелә; чүп өстенә чүмәлә. *Ул һаман чөй өстенә тукмак сугып тора.* Г.Толымбай. **Чөйне чөй белән чыгару** Берәр кыен хәлдән котылу өчен, шуның сәбәбенә охшаш чара табу. *«Чөйне чөй белән сугып чыгаралар» дигән мәкаль дә Сабирҗанның бик исендә иде.* М.Галәү. **Чөйне чөй бәреп чыгара** *к.* **чөйне чөй белән чыгару**. *«Чөйне чөй бәреп чыгара!» дигәндәй, бушап калган урынга Нәзиләбез, Хәзифәбез, Җәмиләбез һәм дә тагын әллә ничәүләр килеп кермәсеннәрме!* Ф.Яхин

**ЧӨЙ** II *и. иск. диал.* Мактау, ярау, юмакайлау. *Көйгә килмәсә, чөйгә килер.* Мәкаль

**ЧӨЙКӘЛТҮ** *ф.* 1) *сөйл.* Түнтәрү, аудару. *Маһир хыялы белән ул тракторны кире якка борып куйды. Ул гына да түгел, чөйкәлтеп үк җибәрде...* М.Шаһимәрдәнов

2) Янтайту, кыйшату. *Өстәлне чөйкәлтү*

3) *гади с.* Аракы һ.б.ш.ны эчеп җибәрү, эчеп кую. *[Гарифҗан:] Тагын берне чөйкәлтәм дә генерал янына чыгам.* А.Гыйләҗев

**Чөйкәлтеп җибәрү** Кисәк чөйкәлтү. *Аның ярдәмендә эчүгә остарып өлгергән Харитон да стаканын бер тында чөйкәлтеп җибәрде.* С.Сабиров

**Чөйкәлтеп кую** Бераз чөйкәлтү, бер тапкыр чөйкәлтү

**ЧӨЙКӘЛҮ** *ф. сөйл.* Аву; янтаю, кыйшаю. *Басма чөйкәлде*

**Чөйкәлеп китү** Кинәт чөйкәлү. *Георгадзе көйманең чөйкәлеп киткән читенә басасы урынга, каушаудан, авышкан якка китереп басты да шундук, мылтыгын тоткан килеш, суга очып төште.* Т.Нурмөхәммәтов

**Чөйкәлеп кую** Бераз чөйкәлү, бер тапкыр чөйкәлү

**ЧӨЙЛӘ́Ү** *ф.* 1) Чөй (*1 мәгъ.*) кагу, чөй кертү. *Баржаны Азов диңгезенең тирән җиренә алып килеп, кингстонын (корабльнең су асты өлешендәге уем капкачы) ачалар, кеше белән тулы трюмны чөйләп биклиләр.* М.Юныс

2) *күч.* Кысрыклау. *Суыр көн дә коллыгыңны! Җаныңнан чыгар чөйләп!* Р.Фәйзуллин

3) *күч.* Алдау. *Сындыралар, сындырталар, Чөйләп тә көйләп кенә.* Э.Шәрифуллина

**Чөйләп карау** Нәрсәнедер белү, сынау максаты белән чөйләү

**Чөйләп кую** Тиз генә яки алдан чөйләү

**Чөйләп тору** Даими чөйләү

**ЧӨЙЛЕГҮ** *ф. диал. к.* **чөйкәлү**. *Кинәт чөйлегеп киткән Резидә Мансурның кочагына килеп чумды, кайнар йөзен аның күкрәк турысына яшерде.* В.Имамов

**Чөйлегеп китү** Кинәт чөйлегү. *Елга уртасына җитәрәк ни күрәбез: салыбызның бүрәнәләре көчле агымнан чөйлегеп китте, без исә уртагарак күченергә мәҗбүр булдык.* Кызыл таң

**ЧӨЙЛЕК** *и. диал. к.* **чөелдерек**. *Җирән биянең чөйлек бавы чияләнгән...* Г.Ибраһимов. *Чөйлек бавы – сары каештан тегеп алынган тасма.* Татарстан яшьләре

**ЧӨЙЛЕКТЕРҮ** *ф. диал. к.* **чөйкәлтү** (*1 мәгъ.*). *Тик кылычын суырып чыгара алмады – туры ыргытылган сөңге, яртылаш күкрәгенә батып, аны шундук артка чөйлектерде.* Н.Фәттах. *Кинәт китереп бәргән кыргый көч безнең очкычны да бер якка чөйлектерде.* Безнең гәҗит

**ЧӨ́ЙСЫМАН** *с.* Формасы белән чөйгә охшашлы, чөйне хәтерләткән. *Аның арпа башагы кебек сары кашлары астыннан өтеп ала торган күз карашы, чөйсыман сакалы, нечкә зәңгәрсу иреннәре арасыннан кысылып чыккан сүзләре нәкъ үзе исән вакыттагыча яңгырый.* Ш.Маннапов

**ЧӨЙЯЗМА** *и. к.* **чөйязу**. *Кече Азия, Месопотамия үзәнлеге, Тигр һәм Евфрат елгалары, Ниневия шәһәре, шумерлар, сугышлар, зиннәтле сарайлар, чөйязмалар...* Г.Тавлин. *Пергаментлар, ташбилгеләр, чөйязмалар!* З.Мансуров

**ЧӨЙЯЗУ** *и.* Алгы Азиядә яшәүче борынгы халыкларда кулланылган, балчыкка яки ташка чөйсыман билгеләр ясап язу ысулы; шул ысул белән язылган язма. *Чөйязу булып эрегән Тояк эзе Далада.* Г.Морат. *Күңелең тарихмы? Чөйязу, ташбилге...* Р.Гаташ

**ЧӨК** *и.* Ашык уенында аткының җиргә төшү рәвеше. *Чөк – бөк – ашыкның җәйпәк йөзендәге чокырлы һәм калку яклары исемнәре.* Г.Исхакый

**ЧӨКЕ** *и. диал.* Шар сугу уены, чәкән шар сугу уены. *[Малайлар:] Әйдә безнең белән чөке уйнарга.* К.Хәмзин

**ЧӨКЕРДӘШҮ** *ф.* 1) Артык көчле булмаган төрле-төрле авазлар чыгару (кошлар тур.). *Кошлар сайрый, кошлар чөкердәшә, Ни куаныч икән кошларда?..* Г.Зәйнашева. *Әнә кошлар чөкердәшә Синең белән минем кебек.* И.Киньябулатов

2) *күч.* Ягымлы һәм йомшак итеп сөйләшү. *Барып керсәм, ни күзем белән күрим: Нәфисә, Сибгать, Сибгатьнең анасы, апасы – барысы бергә чөкердәшә-чөкердәшә сәкедә чәй эчеп утыралар.* А.Шамов

3) *күч.* Аңлашу, тату яшәү. *– Озак кигән эшләпә башка тап-таман була, дигәндәй, без менә хатын белән чөкердәшеп яшибез, – диде Миңнехан, киң күңелле булырга тырышып.* В.Имамов

**Чөкердәшә башлау** Чөкердәшергә тотыну. *Оркыя апа белән Мин Шабай, бик якын кешеләр шикелле, чөкердәшә башладылар.* М.Шабаев. *Туфан: «Яшь чакта без дә шулай итә идек», – дип, кызлар белән чөкердәшә башлый.* Р.Миңнуллин

**Чөкердәшә бирү** Чөкердәшүен дәвам итү. *Ихтыяр, нишләргә дә белмичә, уңайсызланып, Нурисламга карый, ә тегесе күз генә кысып куя да һаман әби белән чөкердәшә бирә.* Р.Вәлиев

**Чөкердәшеп алу** Бераз чөкердәшү. *Үзара чөкердәшеп алдылар.* Г.Гомәр

**Чөкердәшеп тору** Гел чөкердәшү; хәзерге вакытта чөкердәшү. *Яңа өйдә чөкердәшеп торырга вакыты табылыр: алда әле озын көз, аның артыннан сузылып киләсе ак сакаллы кыш бар.* Ф.Хөсни

**Чөкердәшеп чыгу** Билгеле бер вакыт аралыгында чөкердәшү. *Гөлтуташ белән Зифа озын төн буена керфек тә какмыйча чөкердәшеп чыкты.* В.Имамов

**ЧӨКЕ ТАЯК** *и.* Чөке уенында кулланыла торган таяк; кәшәкә

**ЧӨКЕ́-ЧӨКЕ** *иярт.* **1**. *к.* **чырык-чырык**. *Тайга чыпчыклары чөке-чөке киләләр, үзара нигәдер сөенешәләр.* Ә.Маликов

**2.** *рәв. мәгъ.* Ягымлы итеп, чөкердәшеп. *Менә хәзер дә аларның тәрәзә янында янәшә басып торган килеш чөке-чөке сөйләшүләре Габделхәйнең күңелен тырнап куйды.* Н.Фәттах

**ЧӨКРӘ** *и.* Муенның арткы ягында чокырланып торган урын, ялганчы чокыры

**ЧӨКРИ** *этн.* Кайбер йолаларда кулланыла, тары яки арыштан пешерелә, кайвакытта каты була торган икмәк

◊ **Чөкри кычкыру** *сөйл.* Бик нык ашыйсы килү турында. *Аркылысыннан көн яктысы күренә торган шул икмәк кисәген генә ашаган булса да, хәзер аның корсагында бу хәтле үк чөкри кычкырмас иде.* И.Гази. **Чөкри тишеге** *сөйл.* Бик кечкенә бүлмә, торак һ.б.ш.

**ЧӨЛДЕ́Р-ЧӨЛДЕР** *иярт.* 1) *к.* **чөке-чөке**. *Утырабыз шулай чөлдер-чөлдер сөйләшеп, тәрәзә пыяласы зең итеп куйды.* А.Гыйләҗев

2) *к.* **челдер-челдер**. *Юллары – ерак, атлан, чаптыр чөлдер-чөлдер!* Ф.Яхин

**ЧӨЛДИ** *и. зоол. к.* **чуллык**. *Ерганакларда, күлләрдә үрдәк, чөлди, кыр казы, сирәгрәк булса да, торна кебек оялчан дусларыбыз яши.* Ә.Баянов

**ЧӨЛКӘР** *с. диал.* Куе зәңгәр; кара зәңгәр; зәңгәре чак кына беленгән кара

**ЧӨЛЛИ** *и. диал. к.* **чүлли**. *Пинҗәк кесәсеннән чөлли шешәне суырып алган да, Марфа Петровна күрмәгәндә, аракыга чылатып, ипи кисәген ачык тәрәзәдән ишегалдына ыргыткан.* М.Галиев. *Аның сүзләрен тыңлап та бетермәстән, Гайшә түти сулышы капкандай өйгә теркелдәде, ә дигәнче бер чөлли белән матур тәлинкәгә салынган ике өчпочмак тотып йөгереп тә чыкты һәм аларны гәрәбәдәй юылган баскычның уртасына урнаштырып та куйды.* Ф.Баттал

**ЧӨМӘК** *и.* 1) Мичкә, кисмәк, чәпчәк һ.б.ш.ның агызу тишекләрен томалау өчен тыгып куела торган бөке // Шул тишек үзе. *Кызылдан бишек кылдырдым, Алтыннан чөмәк уйдырдым, Көмештән төбәк койдырдым, Уен*

*осталардан уйдырдым, Сырын сырлаучылардан сырдырдым* ---. Дастан

2) Тигез өслектән калкып торган чыгынты. *Кабинаның алгы тәрәзәсенә ара-тирә генә ябышкалаган ак бәс шунда ук күзгә күренеп үсә башлады, һәм, озак та үтми, анда ялтырап яткан боз чөмәкләре барлыкка килде.* Р.Ибраһимов

3) Бүрәнкә

**ЧӨМӘКӘЙ** *с. диал. к.* **чүмәкәй**. *Уч тутырып салган җиләкләрдән зәңгәр чиләкләрем чөмәкәй тулды дигәндә генә, абайламыйча, караеланга баскан күк тидем дә, ул-бу булганчы дип, бөтен урманга шар ярып, алны-артны күрми чабарга тотындым.* Р.Рахман

**ЧӨМӘКЛӘНДЕРҮ** *ф. сөйл.* Чөмәк рәвеше бирү, бөке рәвешенә кертү, бөреп, уймак рәвешен бирү. *Нәзек калдырып кырылган мыекларын тырпайтып, авызын чөмәкләндереп чөңгереп, баланы көлдерергә иткән булды.* Ә.Камал

**ЧӨМӘКЛЕ** *с.* Чөмәге булган. *Зиннәт озын мыеклы абыйның үзен генә түгел, хәтта аның кулындагы чөмәкле таягын да яратмый.* А.Шамов. *Табын уртасына хуш исләре аңкып торган чөмәкле зур бәлеш чыгарылды.* Р.Низами

**ЧӨМӘШҮ** *ф. диал. к.* **чүмәшү**. *Тимучин тирмә эченә узып, түрдә үзе өчен калдырылган иң хөрмәтле урынга чөмәшкән генә иде, ул утырган келәм бер мизгелдә сәер җанланып китте дә, кунак кеше аска – баз эченә чумды.* В.Имамов. *Авыл өйләренең салам түбәләренә чөмәшкән морҗалардан чыккан төтен күздән югалу белән, ягага китүчеләр авылны гел онытып бетерәләр бугай.* К.Миңлебаев

**ЧӨМЕРҮ** *ф. сөйл.* 1) Суырып эчү; зур-зур йотымнар белән эчү. *Батакалка шактый гына су чөмергән малайны солдат Бәдри коткарды.* Н.Гыйматдинова. *Чиләктән пошкыра-пошкыра су чөмерүче кара йөзле ир-атны, чуар күлмәкле хатын-кызны, ялангач балачаганы күргәч, агарынып киттем.* И.Диндаров

2) Сыек ашамлыкны ашау. *Шапыр-шопыр аш чөмергән Идрис, күз кырые белән аны күзәтеп: – Кибеттә идән юасыңдыр, Җәмлә? – диде.* Н.Гыйматдинова. *Мин бу икмәк телемен олы итеп кабам да аш чөмерәм.* Г.Гыйльманов

3) Күп һәм талымсыз эчү; исерткеч эчемлекләрне күп эчү. *Андый зур сабытлар белән Казанда гадәттә сыра чөмерәләр.* М.Маликова. *Әзмәвердәй ике ир заты бер куак төбендә аракы чөмереп калды.* Г.Гыйльманов

**Чөмерә башлау** Чөмерергә тотыну. *Шуны гына көткән Чатан, алдына куйган тәлинкәдән, шупыр-шупыр китереп, токмач шулпасы чөмерә башлады.* А.Хәсәнов

**Чөмереп алу** Бераз чөмерү. *Үзе угылы ясаган чәйне бик тиз генә чөмереп алды.* Г.Исхакый

**Чөмереп бетерү** Беткәнче чөмерү. *Дафар тын да алмыйча кымызны чөмереп бетерде дә бәләкәй сәкегә сузылып ятты.* Р.Батулла

**Чөмереп кую** Бераз чөмерү, бер тапкыр чөмерү. *Абрам Ильич чәркәсендәге эчемлекне чәй эчкән кебек шупырдатып чөмереп куйды да Әдиләгә текәлде.* З.Хөснияр. *[Хәлим] Беренче тәлинкәне шыбырдатып чөмереп куйды, икенчесен сорап алмакчы булды.* Г.Гыйльманов

**Чөмереп тору** Даими, еш яки әледәнәле чөмерү; хәзер чөмерү. *Ак кар өстенә сузылып ятып чишмәдән су чөмереп тора икән диярсең, борын очы хәтта су читенә тиеп үк тора...* Р.Мөхәммәдиев

**Чөмереп утыру** *сөйл. к.* **чөмереп тору**. *Зыя, мөртәт, телефоннан сөйләшү белән рәттән чәй дә чөмереп утыра иде бугай, трубка аша янә голт-голт иткән тавыш ишетелде.* В.Имамов

**Чөмереп яту** *сөйл. к.* **чөмереп тору**. *[Мияссәр:] Шешә авызыннан гына чөмереп ята.* А.Гыйләҗев. *Борчу-кайгысын онытырга теләпме, өч көн буе өендә аракы чөмереп ятты да, җанын җылытырлык, күңелен тынычландырырлык юаныч таба алмагач, Нурулла якты дөньядан китәргә карар кылды.* Г.Гыйльманов

**ЧӨМКӘЮ** *ф. диал. к.* **чүңкәю**. *Крушник, җилкәсендәге ящик почмагы белән кәрзинкә читенә нык бәреп, Закирны чайкалтты. Закир, кәрзинкәсен таккан килеш, «сәҗдә»гә китте, чөмкәйде.* Ф.Сәйфи-Казанлы

**ЧӨН** *бәйл. иск. к.* **өчен**. *Шул теләк чөн сызганылган беләкләрем, Алла кушып мин аларга җитә калсам, Хәятымда күп эшемне мин рәтләрем.* Г.Сөнгати

**ЧӨНИ** *и. рус. диал.* Киез ката, киез итек

**ЧӨ́НКИ** *терк. фар.* Иярчен сәбәп җөмлә составында килеп, иярчен җөмләне баш җөмләгә терки. *Ул, үзенең җиңелчә куркыну тойгысын шулай кичергәннән соң, картын күреп алды булса кирәк, чөнки аның йөзенә кинәт әйтеп бетергесез тирән хәсрәт билгеләре чыкты.* А.Расих. *Урманда яшәгән, андагы тормышны аңлаган кеше анда саклык белән генә басып йөри, чөнки атлаган саен кемнеңдер өе, йорты җимерелә яисә үләннәр сына.* А.Нәҗми

**ЧӨҢГЕРҮ** *ф.* 1) Атны әйдәп, иреннәрне бөреп, эчкә һава тартып чинау яки сызгыруга охшаш аваз чыгару. *Хәсән карт аңа җавап кайтармады, ачу белән кола биясенә чөңгерде – ат Асыл картны узып китте.* Х.Хәйруллин. *Атлары юаш икән: әйткәнне, чөңгергәнне, сызгырганны тыңламыйча, әллә кая сөйрәп китми.* Ш.Маннур

2) *диал.* Кечкенә баланы, кулда тотып, табигый хаҗәтен үтәргә кыстау

**Чөңгереп алу** Кыска гына вакыт чөңгерү. *Мирзаян абзый болай да җитез юырткан атына дилбегә кагып чөңгереп ала.* Ф.Абдуллин

**Чөңгереп кую** Кинәт яки бер тапкыр чөңгерү. *Газинур чөңгереп куйды.* Г.Әпсәләмов

**ЧӨҢКӘ** *и. этн.* Мари хатынкызларының баш киеме

**ЧӨҢКӘЙТҮ** *ф. диал.* Эчеп кую, кәгү. *Алай булса, тагын илле грамм чөңкәйт әйдә!* З.Хәким

**ЧӨҢКӘЮ** *ф. диал. к.* **чүңкәю**. *Ниһаять, арыгач, хәлсезләнеп куллары салынып төшкәч, сулышына буылып, ул дык итеп өстәл артына чөңкәйде.* Р.Кәрами. *– Кара, баткакка чөңкәймә, – дип куйды Зөфәр.* И.Хуҗин

**ЧӨПЧҮ** *ф.* Чокчу, чоку, казу. *Тамбурлы чәнчем – тукыма аша чөпчеп алынган күз ул.* Сөембикә

**ЧӨРӘ** *с. диал. к.* **чүрә**. *Ул кергән йортларның тетелмәгән җирләре, актарылмаган почмаклары, төбе чөрә әйләндерелмәгән сандыклары бер дә калмый.* Г.Галиев

**ЧӨЧЕ** *с. диал. к.* **төче** I

**ЧӨЧЕК** *и. диал. к.* **төчлегән**

**ЧӨЧЕЛӘНҮ** *ф. диал. к.* **төчеләнү**. *Дүрт хатын бергәләшеп бик чөчеләнеп сөйләшеп утырганда, берәү болар янына килеп туктый.* Ф.Сәйфи-Казанлы

**ЧӨЧҮ** *ф. диал. к.* **төчеләнү**. *Үзе төскә чибәр, сылу, кыланышлары сөйкемле, акыл да, сизгерлек тә юк түгел, чөчеп караучылар аз булмас иде аңа...* Ә.Еники

**ЧӨШЛЕ** *и. диал. к.* **шөшле**. *Әсгатеннән соң булган сүләшү – тагы шул чөшле сораганга сырлы бәләк тотбыру булып чыкты.* Ф.Хөсни. *Бу юлы Гәүһәршадның иреннәре җеп шикелле*

*булып кысылды, ияге чөшле кебек алга очлаеп чыкты.* М.Әмирханов

**ЧӨЮ** *ф.* 1) Югарыга ташлау, югарыга ыргыту. *Зәлия, аның саен ярсып, бәрәңгеләрен чөя.* А.Гыйләҗев. *Тимучин якында гына пыскып азапланган бер кисәүне кулына эләктерде дә аны күккә чөйде.* В.Имамов

2) Бик нык куану, шатлануны белдереп, кемне яки нәрсәне дә булса, кулларда тотып, югарыга берничә мәртәбә ыргыту. *Малайлар кызарып бүртенгән Габиулланы җиргә утырттылар да, Нигъмәтнең пышылдап биргән боерыгына буйсынып, бабайга ташландылар. Ул карышып өлгергәнче, аны иплән кенә тотып, бик биек ыргытмыйча һавага чөйделәр.* З.Зәйнуллин. *Мөхәммәтне батыр итеп күккә чөйделәр.* Р.Сибат

3) Көрәштә кемне дә булса күтәреп алып егу. *Сине шул хәрәмләвем аркасында баш аша чөйдем.* Г.Ибраһимов. *[Хәлим:] Сәмигә син инде ник җиде кат бияләй киертмисең – барыбер чөям мин аны!..* Г.Гобәй

4) *сөйл.* Һавага ату, җибәрү (ракета тур.). *Мансур актыккы ракетасын һавага чөйде.* Г.Әпсәләмов

5) Югарырак күтәрү, өскә сузу. *Солтанбикә ияген өскә табарак чөйде.* В.Имамов. *Сәет уйлап та бетерде, үзен-үзе белештермичә, кулларын күккә чөйде.* Г.Гыйльманов

**Чөеп җибәрү** Кисәк чөю. *Таҗетдинов, телефонограмма дигәч тә, җитди кыяфәткә керде, чәчләрен тагын бер мәртәбә артка чөеп җибәрде.* А.Гыйләҗев

**Чөеп йөрү** Гел чөю. *Беренче секретарьның курчактай киенә торган Светлана исемле кызы гына бездән югарырак, ләкин ул берәү белән дә аралашмый, борын чөеп йөри шунда.* А.Тимергалин

**Чөя башлау** Чөергә тотыну. *Башкалар да минут эчендә аның тирәсенә җыелдылар, аны һавага чөя башладылар.* А.Алиш

**Чөя төшү** Бераз чөю; тагы да ныграк чөю. *Сәлим хан, үз боерыгыннан канәгать калып, башын чөя төште.* М.Хәбибуллин

**ЧӨЯЛМӘ** *и. диал.* Кое сиртмәсе

**ЧУ** *и. иск.* Чолгау. *Палузур читекләр эчендә ефәк аяк чуы бар.* Җыр

**ЧУАК** *с.* **1.** *сөйл.* Явым-төшемсез, болытсыз, аяз. *Бүгенгедәй исемдә, якты чуак бер тын иртәдә бала башыма шундый аң килде: бу якты дөньяга минем килмәвем дә бик мөмкин булган лабаса.* Г.Хөсәенов. *Яшибез шулай шөкрана кылып чуак көннәребездә.* Ә.Хәсәнов

**2.** *и. мәгъ.* Явым-төшемсез, аяз, җылы көннәр, шундый ара

**ЧУАЛ** I *и. диал.* 1) Зур капчык

2) Ияр урынына кулланыла торган мендәр

**ЧУАЛ** II *и. диал.* Төтен юлы туры булган мич. *Бишенче көндә янә моны бай чакырып, аждаһа эчереп кайткан күлне киптереп, күл төбенә ашлык чәчеп, булдырып, урып-сугып, суырып, киптереп, тарттырып, он ясап, чуал салып, квашна ясап, апара изеп, ачы камыр белән ачытып, яхшы йомры итеп әвәләп, шул чуалда пешереп, иртә сәгать сигезгә кадәр байга китерергә кушты.* Әкият // Гомумән мич. *Айсылу, куркып, чуал өстенә менеп, анасы да тәрәзәләрне томалап, үзе сәке өстенә менеп, сандык артына яшеренде.* Әкият

**ЧУАЛАНДЫРУ** *ф. сөйл. к.* **чуалту**

**ЧУАЛАНУ** *ф. диал. к.* **чуалу**. *Әлләни уйлавы бар. Нигә бу гел монда чуалана дип...* Т.Миңнуллин. *Хатын-кыз белән күп чуалангач, алардан ныграк шикләнә башлыйсың шул.* З.Хәким

**Чуалана бару** Торган саен чуалану. *Хатны укыган саен уйларым чуалана барды.* Т.Әйди

**Чуаланып бетү** Бик нык чуалану. *Аңа чәчләре чуаланып беткән, күз төпләре шешенгән бер өрәк карап тора иде.* Х.Ширмән

**ЧУАЛТМЫШ** *и.* Булмастай хәлләрне бәян итүгә корылган абсурд эчтәлекле, кыска сүз уйнату жанры. *Чуалтмышлар исә халкыбызның җорлыгын да, тапкырлыгын да, көр күңеллелеген дә ачык чагылдыра.* Р.Миңнуллин. *Димәк, кайбер җор әкиятчеләр, тыңлаучыларның кәефен күтәрү өчен, әнә шундый такмаза-чуалтмышларны да кулланганнар.* Л.Җамалетдинов

**ЧУАЛТУ** *ф.* 1) Төенләү, чиyләндерү. *Егет кыз катына барганда үзенең билбавын да бик чуалтып бәйли, очларын адәм табалмаслык итеп яшереп куя.* Г.Ибраһимов

2) Бер-берсе яки икенче нәрсә белән аралаштыру. *Мутлыкта йөреп, кәҗә ак сакалын чуалтты, бер мөгезен югалтты.* Н.Әхмәдиев. *Чәчемне чуалтасың, Юриме шаяртасың?* М.Шабаев. *Алар ярылып яткан эзләрне дә бүтән эз белән чуалталар, берни булмагандай, озак вакыт яшеренеп йөриләр.* М.Насыйбуллин

3) Берсен икенчесеннән аермау, бутау. *«Татар теленең фразеологиясе, мәкаль һәм әйтемнәре» дигән китапта, исеменнән үк күренгәнчә, мәкальләр белән әйтемнәр аермасыз бергә җыелып, чуалтып бирелгәннәр.* Н.Исәнбәт

4) Берәр эштә катнашырга, берәр нәрсә яки кем тирәсендә йөрергә ирек кую, шуңа мөмкинлек бирү. *[Мохтар:] Авыру янында чуалту кирәкмәс иде андый халыкны.* Ш.Камал

5) *сөйл.* Кыенлаштыру, читенләштерү, катлауландыру; бутау (эшне һ.б.ш.). *Мантыйксыз-нисез мәсьәләне чуалталар иде.* Г.Исхакый. *Эшнең болай борылуы минем алдагы планнарны тәмам чуалтты.* А.Гыйләҗев

6) Бәйләнешен, эзлеклелеген, ачыклыгын бозу; буталчыкландыру (фикер, уй, аң һ.б.ш. тур.). *Шулай матур уйларга чумган чакта, аның алачак-бирәчәкләре фикерен чуалтты.* А.Алиш. *Мәрьямбикәнең төссезләнеп пыялаланган күзләре, боз булып укмашкан чәчләре аның уйларын чуалтты.* С.Зыялы

**Чуалта бару** Торган саен ныграк чуалту. --- *юл башында тез тиңентен, тора-бара исә бил тиңентен үк кар ерып бару, әле беребезнең, әле икенчебезнең егылып китүе яки арып утырып калулары бу бишлекләрне чуалта барып, ары таба рәтләребезне бөтенләйгә таркатып бетерде.* Р.Сафин

**Чуалта башлау** Чуалтырга тотыну. *Әбекәйнең йомгагын Мәче чуалта башлый.* Ф.Яруллин. *Өн белән төш арасында буталулар Роберт Хисамовичның уйларын чуалта башлады, кайчакта шул кешеләр халәтендә сизеп кала ул үзен.* К.Кара

**Чуалта бирү** Бернигә карамый чуалту. *Әллә ни эшләп көннән-көн мәсьәләне чуалта бирә һәм көннән-көн койрыгын ераграк яшерә бирә.* Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар

**Чуалта төшү** Бераз чуалту; тагын да чуалту. *Бу ария аның образын ачмый, киресенчә, тагы да ныграк чуалта төшә.* М.Җәлил. *Әмма бу революция болай да чуалчык тормышны тагын да чуалта төшә.* Т.Насыйров

**Чуалтып алу** Бик кыска вакыт эчендә чуалту; вакытлыча чуалту. – *Бер дәрәҗәдә фикерләр чуалтып алыр өчен, бәлки, файдасы тияр иде,* – *диде.* Г.Баруди. *Шулай да Хәмит исемле бер Илеш кешесе хисләрен чуалтып алды.* М.Әмирханов

**Чуалтып бетерү** Тәмам чуалту. *Бүгенге кыланышлары белән фикеремне тәмам чуалтып бетерде.* А.Гыйлә-

җев. *Эшне бөтенләй чуалтып бетермик тагын!* Р.Гаязетдин

**Чуалтып җибәрү** Көтмәгәндә яки бераз чуалту. *Ул бу шигырен, үзе дә сизми, шул русча шигырьгә ияреп язмады микән – бу фикер Вәлинең башын бөтенләй чуалтып җибәрде.* Гали Рәхим. *Егетнең сүзләре, Зареманың йөрәгенә үтеп кереп, уй-фикерләрен бөтенләй чуалтып җибәрде.* И.Диндаров

**Чуалтып йөрү** Әле чуалту; озак вакытлар дәвамында чуалтып тору. *Белмим, санамадым, кит, зинһар, фикерне чуалтып йөрмә!* Г.Кутуй

**Чуалтып кую** Кисәк чуалтып җибәрү. *Җитәкчебезнең, иртәгә китәбез, диюе, болай да үзенә урын таба алмыйча интеккән җанымның тынычлыгын алып, бөтенләй фикеремне чуалтып куйды.* Н.Әхмәдиев

**Чуалтып ташлау** Кисәк чуалту. *Әле минә хәерсез бер теләк – үч алу теләге, күңеленең кай төшендәдер давыл кебек кузгалган әлеге хис, хатынның башын чуалтып ташлады.* З.Хөснияр. *Теге хатын тәмам зиһенебезне чуалтып ташлаган бит, каһәр суккыры, сизми калганбыз.* М.Маликова

**Чуалтып тору** Даими чуалту; әле, хәзер чуалту; вакытлыча чуалту. --- *һәлак булган Вафинның семьясы ярымподвалда яши бит! Шул зиһенемне чуалтып тора.* М.Хәсәнов

**ЧУАЛУ** I *ф.* 1) Тәртипсез рәвештә үрелү, ишелү, бәйләнү, төенләнү. *Ике кулын урындык артына җәеп салган, бүреге артка шуган, чәче киң маңгаена чуалып төшкән, йөзе җитди дә, кырыс та.* Г.Әпсәләмов. *Әнә ничек күбеккә батып кайта бахбайлар. Яллары чуалып, үрелеп беткән була...* Г.Гыйльманов

2) Төрле якка тәртипсез рәвештә тармаклану, кисешү. *Офыклар кап-кара, юллар чуалган, бара-бара да әллә кая – янга каерылып кереп китә ---.* А.Гыйләҗев

3) Атлаганда аяк эләгеп ычкына алмау, бәйләнеп калу. *Зәнә нәрсәгәдер абынып чуалып егыла.* А.Гыйләҗев

4) *сөйл.* Кем белән дә булса аралашу, берәр төрле эш йөртү. *Ул бит башта эсерлар тирәсендәрәк чуалган иде, диләр.* Г.Ибраһимов // Якын мөнәсәбәттә, мәхәббәт, интим бәйләнештә булу. *Имеш, Фатыйма Булат дигән бер студент белән чуала, Вафаны ташлаган икән.* А.Алиш. *Бездә булган мәгълүматларга караганда, бу әфәнде Маруся исемле бер матуркай белән чуалган, ди, хатыны өстеннән.* Г.Афзал. *Ник соң гаиләле кеше белән чуалдың?* З.Кадыйрова

5) *сөйл.* Мәшгуль булу, маташу. *Яшьләр шунда кайнашыр, карт-коры кунаклашу, арчи алу, үзара сыйлашу белән чуалыр.* Г.Ибраһимов. *Килү мәшәкате белән чуалып, безнең дә күз җитмәгән.* А.Гыйләҗев

6) *сөйл.* Мәгънәсез, файдасыз яки ярамаган эш белән шөгыльләнү. *Баткаклыда шундый эшләр белән чуала торган бер карчык бар, диләр ие.* В.Нуруллин. *Партия әгъзасы булмагач, вестибюльдәге милиционерга паспортымны калдырып, ниндидер бер рөхсәт кәгазе алу күңелне болгаткан һәм инде кабат бу тирәдә чуалмаска дип үз-үземә сүз биргән идем.* А.Тимергалин

7) *күч.* Кем яки нәрсә тирәсендә булу, кайнашу, булашу. *Син, шәкерт, изгеләр тирәсендәрәк чуала торган кеше ---.* Г.Әпсәләмов. *Миннән үрнәк ал, картлач: берәүгә дә гашыйк түгел, ә кызлар тирәсендә чуалырга яратам үзем.* А.Тимергалин. *Наил абыйсы янында чуалырга яраткан Булат бүген түзеп торамы соң инде?!* В.Нуриев // Берәр нәрсә тирәсендә яшеренлек саклап, күренмәскә, танытмаска тырышып кына булу. *Һәркайсы Апанаевлар хәзинәсе янында чуалган кеше турында уйлады.* А.Тимергалин // Берәр кеше янында булып, аны тынгысызлау, аңа комачаулау. *Биредә аларга берәү дә тими, алар кешеләргә шулхәтле ияләшкәннәр, чебиләр кебек, аяк астында чуалалар, бер дә курыкмыйлар.* Г.Әпсәләмов. *Аяк астында чуалып йөрсә дә, Актырнак үзенә күрә бер иптәш, юаныч әле.* З.Хөснияр

8) *күч.* Катлаулы, читен булып китү, кыенлашу. *Өмид юк шул, эш көннән-көн бит чуала ---.* Г.Камал. *Дөньялар чуалды, чыгырыннан чыкты.* Г.Бәширов. *[Шәйхел:] Планнар минә шулай чуала инде ул, Сәләхи!* А.Гыйләҗев // Аңлау, төшенү авырлашу, эзлеклелеге, ачыклыгы югалу. *Хәзрәтебез төш күрә башлады, ләкин төшләре әллә ничек тәртипсез чуалып баралар иде.* Ф.Әмирхан

9) *күч.* Бәйләнеш югалу, төзеклек югалу, буталчыклану (фикер, уй һ.б.ш. тур). *Тукта, уйларым чуалды бит әле.* А.Вергазов // Аңлату сәләте киму, баш түнү. *Күренмәс кеше булганнан бирле, аның мие чуалды.* Г.Кутуй. *[Гандәлиф:] Ни уйларга белмим, башым чуалды.* А.Гыйләҗев

◊ **Чуалып калу** Аптырау, нишләргә белмәү. *Кәләшенең әнкәсе бөтенләй чуалып калды: кияүне кая утыртырга, ничек сыйларга белмәде.* М.Салтыков-Щедрин

**Чуала бару** Торган саен чуалу. *Ләкин, шуларның һәммәсеннән дә Хәмитнең башындагы өйләнү дигән уй, фикер чуала гына барды, һәрбер яңы сүздән соң, аның фикере, аның теләгәненчә иттереп бетерелүе авырая гына барды.* Г.Исхакый

**Чуала башлау** Чуалырга тотыну. *Уйларым, фикерләрем чуала башлады.* И.Салахов. --- *сул як аягына чатан Ихсан чуала башлады Хәлимә тирәсендә.* А.Хәйретдинова

**Чуала бирү** Һаман чуалу; бернигә карамый чуалу. *Бала мәсьәләсенең хәбәре көне белән Җәләлгә ирешсә дә, бу утызныкы ничектер яшерелгән; мулла аны унбиш көн үткәч кенә ишетте; ләкин күп әһәмият бирмәде; җә ни булыр тагы дип, баштагы авыр вә билгесез мәсьәләләре белән чуала бирде.* Г.Ибраһимов. *Юмба көн саен шунда чуала бирде.* Г.Әпсәләмов

**Чуала килү** Хәзергә кадәр чуалу. *Иске гадәт белән ясалып куелган кагыйдәләр булмаганга, шундый әфәләм төрле өйләнүләрне гомерендә күрергә тугры килмәгәнгә, вакыт үткән саен, фикер чуала гына килде ---.* Г.Исхакый

**Чуала тору** Әлегә чуалу. *Батый абзасы, күз-колак булып, шул тирәдә чуала тора...* М.Хәсәнов

**Чуалып алу** Берникадәр чуалу. *Унбишкә кадәр санавым булды, өчпочмакның бер канаты чыннан да чуалып алды.* Г.Бәширов

**Чуалып бетү** Тәмам чуалу. *Хәтер чуалып беткән.* А.Гыйләҗев. *Көне буена ул [бичәүкә я чабата киндерәсе] чуалып бетә.* А.Хәсәнов

**Чуалып калу** Берәр нәрсә ахырында чуалган хәлгә килү. *Утын төягән баржа, буксир, балыкчы көймәләренә, эллингларның рәшәткәле краннары арасында чуалып калган төтен сәләмәләренә карасу шәфәкъ кызыллыгы төшкән.* А.Толстой. *Шуны уйлау гына да үзеннән-үзе каушата, кайвакытны дулкынланудан хәтта әйтер сүзләрең дә тиешенчә әйтелми, фикер чуалып кала.* Шәһри Казан

**Чуалып китү** Кинәт чуалу. *Ул ничектер зиһене чуалып киткәнен сизде.* Г.Бәширов. *Ләкин минә быел, уйламаганда-көтмәгәндә, Гасимә белән чуалып китте бит, шайтан алгыры!* В.Нуруллин

**Чуалып тору** Гел яки әледән-әле чуалу; әле чуалу. *Хәдичә туташ шул уйлар берлә чуалып торганда, шул матур сүзләр берлә ләззәтләнеп гомер үткәргәндә, Галим абзый, Хәдичәнең сәгадәтенең вакыты җитте дип, мәхдүмне Бохарадан кайтарды.* Г.Исхакый. – *Ачуланма, Фәгыйлә, булдырып булмас, – диде хатынның такылдавыннан туярга өлгергән Шәмсенур әби, – әллә нишләп бу араларда зиһенем чуалып тора ---.* А.Әхмәтгалиева

**ЧУАЛУ** II *и. к.* **чуалыш**. *Әгәр Думаны тиз куып, безне чыгарырга өлгерә дә алмый башласалар, Дума өчен халык арасында тагы чуалулар башланачак иде.* Г.Исхакый

**ЧУАЛЧЫК** *с.* **1.** 1) Чуалган, буталып беткән; тузгыган. *Аның катлаулы механизмы, чуалчык пружиналары киләләр дә күз алга басалар.* Ш.Усманов. *Хыялый яшьләрнең яшьлектәге күп кенә якты, ихлас хыяллары бу тормышның кырыс вә чуалчык ятьмәләрендә уралып юкка чыга күрмәсен иде!* Р.Низамиев

2) Авыр, катлаулы, читен, буталчык. *Ул анда иң авыр, иң чуалчык эшләрне дә ерып чыга ала торган зур начальникны күрде.* Г.Кутуй. *Азмыни бу чуалчык заманда андый шаккатыргыч хәлләр!* Г.Бәширов // Төгәл булмаган. *Партия әсәрләрендә механик, чуалчык тәрҗемә кылу нәтиҗәсендә, аерым сүзләрнең, җөмләләрнең мәгънәләре бозылды.* Ф.Сафин

3) Буталчык, ачык булмаган, бәйләнешсез, эзлексез, логикасыз. *Авыр, чуалчык төшләр белән саташа-саташа йокыга китте.* Г.Ибраһимов. *Авыр уйларымны, чуалчык фикерләремне бер тәртипкә китерер өчен генә язам мин аларны.* Г.Кутуй

**2.** *и. мәгъ.* Буталчык хәл, буталчыклык. *[Солтан:] Әй, вак-төяк чуалчык була ла эштә!* А.Гыйләҗев. *Бу чуалчыкны чишү юлы, хокукый сферадан битәр, сәяси һәм хәтта фәлсәфи сферадан тора.* Р.Хәкимов

**ЧУАЛЧЫКЛАНУ** *ф.* Чуалчык булып китү. *Тормыш чуалчыкланмасын иде...* М.Хуҗин

**Чуалчыклана бару** Торган саен чуалчыклану. *Менә шундый икеле-микеле уйлар белән газапланып утырды Рәйсә ханым, ләкин уйлаган фикерләре чуалчыклана гына барды.* В.Имамов

**Чуалчыкланып бетү** Тәмам чуалчыклану. *Учма төбе чуалчыкланып бетә.* Ш.Маннур

**ЧУАЛЧЫКЛЫ** *с. сөйл. к.* **чуалчык**. *Әлегә кадәр бездә бу мәсьәлә бик чуалчыклы булып килде.* Г.Алпаров

**ЧУАЛЧЫКЛЫК** *и.* 1) Чуалчык булу сыйфаты. *Башында – башкалар язмышы, күңелендә чишелмәгән проблемалар чуалчыклыгы, кулында – кәгазь дә каләм...* К.Тимбикова

2) Чуалчык нәрсә. *Әмма бүген күңел тынычланмады, миендә кайнаган чуалчыклык бетмәде.* М.Галәү. *Шунлыктан чыганак итеп ямьсезлек, мәгънәсезлек, чуалчыклык һәм башка, кешеләр тормышындагы шундый тискәре күренешләр алынырга мөмкин.* К.Гыйззәтов

**ЧУАЛЫШ** *и.* 1) Чуалу, буталып бетү күренеше. *Әхәт турында, ике килми торган гомер турында, эше турында, аннан тагын Әхәт турында өзлексез уйлар чуалышында интегеп, йокысыз ята иде...* А.Гыйләҗев

2) Нәрсәдән дә булса күмәк ризасызлык белдереп хөкүмәткә каршы чыгу. *Элек бу авылда чуалышлар, кузгалышлар, баш күтәрүләр, сугышлар булмаганмы?* Гали Рәхим. *Әби патша заманында торналылар Батырша чуалышында катнашалар, аннары Пугач кузгалышында...* А.Тимергалин

3) Тәртипсезлек; ыгы-зыгы, шау-шу. *Яшүсмерләр чуалышы*

**ЧУАЛЫШУ** *ф. сөйл.* 1) Буталышу; тәртипсез хәлгә килү. *Күнде егет, кызга аркасын куеп, чуалышкан үләннәрне, алар арасыннан йөгерүче бөҗәкләрне күзәтте.* М.Хуҗин. *Күңелендә аның күптөрле сораулар чуалышты.* Ф.Яруллин

2) Бозылышу. *Марат белән мәңге дус булыгыз, безнең төсле чуалышып, ызгышып маташмагыз.* А.Гыйләҗев. *Габбас малайлары, чуалышып, башка чыгарга йөриләр иде бугай ---.* Ф.Яруллин

**Чуалышып алу** Кыска гына арада чуалышу. *Башында диссертация яклау артыннан йөргәндәге вакыйгалар чуалышып алды.* М.Әмирхан

**Чуалышып бетү** Бик нык чуалышу. *Бөтен тәндә рәхәт арыганлык тоела, бит урталары яналар, әле генә киткән күңелле кичнең төрле-төрле тойгылары башта чуалышып бетеп кайнашалар.* Ф.Әмирхан. *[Аклар] тау арасында сугыша белмиләр икән, чуалышып беттеләр.* Г.Бәширов

**ЧУАН** *и.* Тиренең төк капчыгы һәм май бизе ялкынсынудан барлыкка килгән эренле шеш. *Менә синең тәнеңә бервакыт азгын чуан чыга.* Г.Әпсәләмов. *Авырып егылдым, бөтен тәнемне чуан басты.* Н.Гыйматдинова

◊ **Чуанына басу** *к.* **чуанына тию**. *Ә теге һаман ду куба, чуанына баскannар диярсең.* М.Хәбибуллин. **Чуанына кагылу** *к.* **чуанына тию**. *Анысын тагын кем белгән – бәлки, Лазаревның чуанына кагылу булыр бу...* Ә.Баян. **Чуанына тию** Кемне дә булса борчыган, газаплаган мәсьәләне кузгату

**ЧУАР** *с.* 1) Өслеге төрле төстәге, төсле-төсле чәчәкләр, таплар һ.б.ш. төшкән (гадәттә тукыма тур.). *Тимер баганалы капканың келәсе чык итте дә, аннан чуар яулыклы бер баш күренде.* З.Хөснияр // Бик күп төс катнашкан. *Күк йөзе, иңеннән иңенә, буеннан буена җилләткән чуар ефәк тасмалар кебек, төрле төскә кереп, балкып яна икән.* Г.Әпсәләмов

2) Кара яки карасу таплы; аклы-каралы, аклы-кызыллы (хайваннар, кошлар тур.). *Мич кырыенда салам өстендә чуар бозау.* Г.Әпсәләмов. *Тәрәзә төбендәге кына гөле чүлмәге янында, бөгәрләнеп, чуар песи Кушты йоклый.* А.Гыйләҗев

3) Төрле төсле, төрле төстәге таплары булган (кош, бөҗәкләр). *Чуар күбәләк чәчәкләргә кунып уйный ---.* Г.Хөсәенов. *Чебешләренә куркыныч янаганда, хәтта чуар тавык та, үзен-үзе белми, тилгән-карчыга, хәтта бөркет өстенә ташлана.* А.Хәсәнов

4) Төсе тоташ булмаган, кайда куе, кайда сыек булган. *Кояшны каршы алырга офык артыннан чыккан юка, чуар болытлар алсу нурга манчылдылар.* А.Гыйләҗев

5) Төрле-төрле, бер иштән булмаган; төрле элементлардан торган. *...Учредительный собраниягә бик төрле вә чуар спискалар үтте.* Г.Исхакый. *Сораулар чуар һәм катлаулы.* Г.Гомәр

6) *күч.* Төрле-төрле күренешләрне, вакыйгаларны үз эченә алган. *Әллә нинди чуар, ямьсез төшләр кереп йөдәттеләр...* А.Гыйләҗев

7) Тотрыксыз, үзгәрүчән. *Тормыш чуар ул, шиңгән колак!* А.Гыйләҗев. *Дөнья чуар, дөнья катлаулы, дөнья биниһая киң – шул киңлекләрне иңләтеп йөртә безне язмышлар.* Б.Камалов

8) *күч. сөйл.* Җиңел һәм еш үзгәрүчән, даими булмаган, тиз алышынып торган (хис-тойгы һ.б.ш.). *Күренеп тора: уйлары, хисләре чуар иде аның, тәртипсез иде.* Г.Гыйльманов. *Ул һәр укучының күңеленә яхшылык сеңдерергә тырыша, акыл байлыгына хуҗа була белергә өйрәтә, чуар фикерләр, хисләр,*

*вакыйгалар буталчыгында дөрес юл табарга булыша.* Ватаным Татарстан

◊ **Чуар йөрәкле** 1) Тынгысыз, гел борчыла, дулкынлана торган. *Әти, син чуар йөрәкле кеше, мин сине беләм, син тагын, мин моны булдырам әле дип, көрәк белән бакчага чыга күрмә.* М.Мәһдиев; 2) Мәхәббәте җиңел һәм еш алышынып торган, хисләре даими булмаган. *Мондый чуар йөрәкле егетнең сөйгәне булмау да гаҗәп түгел.* А.Гыйләҗев. **Чуар күңелле** *к.* **чуар йөрәкле**. *Әнә теге ала сыерның хуҗасы да – кērделечыктылы, чуар күңелле адәм.* Х.Камалов. *Утызга җитеп килә торган, акыл утырткан, төчесенә караганда тормышның ачысын мулрак эләктергән егет, башкалар чуар күңелле җилбәзәк дип санаган, куркыныч матурлыкка ия булган шушы кыз белән ничек танышa, дуслаша алды икән?* А.Гыйләҗев. **Чуар холыклы** *к.* **чуар йөрәкле**. *Яшь хатыннарның чуар холыклырак булуларын беләбез.* А.Хәсәнов

**ЧУАРБАЛЫК** *и. зоол.* Сөләйман балыклар семьялыгыннан күбрәк соргылт күк, ак төсләрдәге зур булмаган балык; *русчасы:* **ряпушка**. *Төче су балыклары – керкә, Байкал омуле, Чуд алабалыгы, чуарбалык та – кыйммәтлелеге ягыннан алардан калышмый.* Биология. Хайваннар

**ЧУАРБАРЫС** *и. зоол.* Мәчечәләр семьялыгыннан капланга охшашлы эре ерткыч хайван; ягуар

**ЧУАРЙӨРӘК** *и.* 1) Тынгысыз, гел борчыла, дулкынлана торган кеше. *Аның бу сүзләреннән соң кайсыдыр чуарйөрәк, кайнарбаш аркасында килеп чыккан әлеге конфликтны ике як та аннулировать итәргә әзерләр.* А.Хәсәнов

2) Мәхәббәте җиңел һәм еш алышынып торган, хисләре даими булмаган кеше. *Сукмактан сукмакка кереп адашып йөри торган гадәте булса да, Сәлимнең чуарйөрәк түгеллеген мин белә идем.* А.Тимергалин. *И бала, җүнсез бала, бер хатынны ташлый, икенчесен башлый: бигрәк чуарйөрәк инде, тач атасы инде!* Н.Гыйматдинова

**ЧУАРКОҢГЫЗ** *и. зоол.* Йөзгәләкчәләр семьялыгыннан буаларда яшәүче тутык сары төсендәгерәк зур булмаган коңгыз; *русчасы*: **пеструшка**

**ЧУАРКӨПШӘ** *и. бот.* Сабагы чуар булган, яшь көпшәсе ашарга яраклы үләнчел үсемлек. *Карга борынының тамарга торган җиләген ашыйбыз, шепкән уабыз. Шомакөпшә, сасыкөпшә, чуаркөпшә. Җаның ни тели!* А.Гыйләҗев. *Яз җитүгә, сары чәчәк, үги ана яфрагы чәчәге, чуаркөпшә, кузгалак, какы ашый идек.* Туган як

**ЧУАРКҮБӘЛӘК** *зоол.* Чуаркүбәләкчәләр семьялыгыннан нигездә кызыллы-каралы төстәге күбәләк; *русчасы:* **пестрянка**

**ЧУАРКҮБӘЛӘ́КЧӘЛӘР** *и. зоол.* Тәңкәканатлылар отрядыннан канатлары эре тимгелле күбәләкләр семьялыгы

**ЧУАРКҮҢЕЛ** *и. к.* **чуарйөрәк**. *...Чуаркүңел, белмим, түзалырмы – Сабырлыклар бирсен!* Р.Гаташ

**ЧУАРЛАНДЫРУ** *ф. к.* **чуарлату**. *Аларның бакчаларында, каен агачлары һәм карт өянкеләр астында, Фатыйма абыстай пешергән тәмле чәй ашлары белән чәй эчү ара-тирә минем бертөрле тормышымны чуарландыра иде.* Г.Рәхим. *Халык белән тулы мәйданны шарлар чуарландыра.* Кызыл таң

**ЧУАРЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **чуарлау**. *Һәркайсының бер ягы чиста, язылмаган, ә икенче ягы гарәп хәрефләре белән чуарланган.* А.Тимергалин. *Миңниса йолдызлар белән чуарланган күк йөзенә төбәлде дә уйга чумды.* А.Фәләх

2) Чуар төскә керү, чуарга әйләнү, чуар булу. *Колын үсә төшкәч чуарланды*

3) *сөйл.* Күз ачык күрмәс хәлгә килү, күз алды караңгылану; чуарлык барлыкка килү. *Минем күз алларым чуарланды; гәүдәм авырланып китте вә көчкәкөчкә генә әллә кайда, бакчаның артына, кеше йөрмәгән бер җиргә барып утырдым.* Ш.Камал. *Башта мин каушадым. Күз алдым чуарланды.* М.Гафури

**Чуарлана бару** Торган саен чуарлану. *Шуңа дәлил рәвешендә, үзе җитәкчелек иткән газетага килгән шигырьләрнең саны күбәюен, тел-стильләренең чуарлана баруын атый.* Т.Галиуллин

**Чуарлана башлау** Чуарлану билгеләре күренү. *Туры бурлы булып туган кайбер колыннарның сабыйлык йоны бераздан соң тәңкә-тәңкә булып чуарлана башлый икән.* Г.Ибраһимов. *Тышка чыкканда, майорның күз аллары чуарлана башлаган иде.* Г.Әпсәләмов

**Чуарлана төшү** Бераз чуарлану. *Тик китаплар, гәзитләр шүрлеге янында Фәхринең фронтта гаскәри киемдә алдырган бер рәсеме арткан да Самат белән Азатның өстәлгә пычак белән чокыган язулары тагын тирәнәя, яңара, тагын чуарлана төшкән иде.* Г.Ибраһимов

**Чуарланып бару** *к.* **чуарлана бару**. *Ләкин язу, матбугат, әдәбият теле, баштарак, бер яктан – иске гарәплек калдыклары, икенче яктан, яңа кергән чит сүзләр белән чуарланыбрак барса да, көннән-көн алардан сафланып, төзек бер эзгә төшеп бара.* Г.Алпаров

**Чуарланып бетү** Тәмам чуарлану. *Комбат үзенең чуарланып беткән картасына Газинур тапкан киртәне дә төшереп куйды.* Г. Әпсәләмов. *– Әйе-е-е, Хәмит, – дип сузды ир һәм янында басып торучы картның өс-башын, сакалмыек баскан йөзен, тирән җыерчыклар белән чуарланып беткән кулларын, сәләмә киемен күздән кичерде.* А.Фәләх

**Чуарланып калу** Берәр нинди эшшөгыльдән, вакыйгадан соң чуарланган хәлгә килү. *Кайберләре, карындык төсенә кереп, чуарланып калган.* Н.Хәсәнов

**Чуарланып киту** Кинәт чуарлану. *Бу елны да, вакыйгалар чуарланып китүгә карамастан, ул бары тик шушы Галимҗан абыйсының дәресләрен ишетми калмыйм дип, мәдрәсәгә кабат керде.* Ф.Яхин. *Ишеткәннәрдән тәнгә салкын тир бәреп чыкты, күз аллары чуарланып китте.* Я.Шәфыйков

**Чуарланып тору** Әле чуарлану. *Чамасыз яңгырдан соң, җиргә борчак шактый коелган. Ап-ак булып чуарланып тора – игенченең борчак-борчак хәләл тирләре әрәм тәгәрәп ята.* Ш.Галиев

**ЧУАРЛАТУ** *ф.* Чуар итү, чуарга әйләндерү. *Ялтырап яткан Идел өстен чуарлатып, салмак кына саллар ага.* Т.Гыйззәт. *Шулай булуы мөмкинлеген алдан ук күрә белде, аһ-ваһ итмәде, зирәк акыллы картларча аңа алдан ук әзерләнде, бәлки, бәлки, дип, күңелен дә чуарлатмады.* Безнең мирас

**ЧУАРЛА́У** *ф.* 1) Чуар итү, чуар төскә кертү. *Хәзер «Ургыл»ның тышкы күренеше элеккечә тоташтан зәңгәрсу ак түгел, ә яшькелт сары төскә алакола чуарлап буялган һәм сирәк урманлы тау битенә охшап калган.* С.Сабиров

2) Бизәү; бизәкләү. *Ул гына түгел әле, җитен киндерен чуарлап суга торган җирләр дә бар икән.* Г.Камал. *Мужик егетләрнеке төсле иттереп, читләрен чуарлап бәетләр язарга миңа килешми.* Г.Исхакый

3) Бик күп билгеләр төшерү, языпсызып тутыру. *Өстәлгә төрле төскә буялган материалларны җәеп сала да, сүзен дәлилләп, ак кәгазь битләрен сызымнар белән чуарлый, ачышлары турында ялкынланып-кайнарланып сөйли ---.* Х.Бәдретдинов

4) Берәр элемент кертеп, нәрсәнең дә булса кыяфәтен, гадәттә, тискәре якка үзгәртү. *Аккаунт тасмасын реклама белән чуарлыйсым килми.* Әлмәт таңнары

5) Шадраландыру. *Актайның сапсары комы өстеннән тыныч кына аккан сай суны чуарлап, җылы җил исеп куя.* Ә.Хәсәнов

6) Каплау, каплап алу, сырып алу. *Бөтен болын өстенә, күз күреме җирне чуарлап, әллә никадәр печәнче сибелгән.* Г.Бәширов

7) Берәр нәрсәнең элементларын төрле-төрле итү. *Телнең лексик составына килгәндә, аны ясалма рәвештә икенче милләтләрнең сүзләре белән чуарлап булмый ---.* Ф.Галимуллин

8) Тотрыклылыгын бетерү, тиз үзгәрүчән итү. *Шушы иркәлек баланың күңелен бик тиз чуарлый да инде.* Безнең гәҗит

9) Сөйләмдә, язмада эчтәлеккә бик үк карамаган сүзләр куллану; төче, нәзакәтле сүзләр кыстыру. *Лиза күрше дачаларында тора торган Евгений исемле бер яшь офицер белән үзе арасында булып үткән вакыйганы бик озайтып, бик чуарлап сөйләде.* Ф.Әмирхан. *Ул матур буяуларга чуарлап бирелмәгән.* Р.Зарипов

**Чуарлап алу** Тиз генә чуарлау; бөтенләй чуарлау. *Кар белән кыш дәвамында капланып торган чүп-чарлар җиребезне чуарлап ала.* Әлмәт таңнары. *Шулай булмаса, ял көннәрендә елга-күл өсләрен биләп, бәкеләр белән чуарлап алмаслар иде.* Маяк

**Чуарлап бетерү** Бөтенләй чуарлау. *Шәһәр читендәге пристаньда да урман кебек торган сәүдә көймәләренең машларына флаглар тагылган, аларны төрле төсләр илә чуарлап бетергән иде...* Н.Думави. *Атаң, безнең өйне салганда, бөтен җирне күгәрченнәр белән чуарлап бетергән иде.* Л.Лерон

**Чуарлап җибәрү** Бераз чуарлау. *--- чуарлар үз клубларын артыгы белән чуарлап җибәргән лә, дияргә булыр иде хәтта.* Э.Касыймов

**Чуарлап чыгу** Һәрберсен берәмберәм чуарлау. *--- кульязманы, өстендә генә төзәтеп чуарлап чыгабыз да, шул хәлендә типографиягә җибәрәбез.* М.Әмир

**Чуарлый башлау** Чуарларга керешү. *Бармак башыдай гына карандаш кисәге аны тиз-тиз чуарлый башлады.* Ш.Маннур. *Габдулла Тукайның бу шигъри юллары шундый тәэсирле, серле, мавыктыргыч яңгырый ки, биш яшьлек сабый, тылсымлы сүзләрнең сихеренә бирелеп, дәфтәр битләрен чуарлый башлый.* Т.Әйди

**Чуарлый тору** Әлегә чуарлау; һаман чуарлау. *Шулай да хәбәр артыннан килгән яңасы дөньяны чуарлый торды, нефть хакындагы сүзләрне искәртте, ахырда, озаккадыр, оныттырды...* Ф.Яхин

**Чуарлый төшү** Бераз чуарлау

**ЧУАРЛЫК** *и.* Чуар булу сыйфаты. *Милли яктан чуарлык бик көчле: монда рус, казах, татар, украин, кыргыз, үзбәк, яһүди...* М.Мәһдиев. *Шушы урында, яңа танышыбыз турында сөйләүдән читкәрәк китеп, Рафаэльнең холкындагы әкәмәт тә һәм хикмәтле дә чуарлыкны әйтмичә ярамас.* М.Хуҗин

**ЧУАРТАРАКАН** *и. зоол.* Кызыл кандалалар семьялыгыннан кара өслектә кызыл таплары булган җир өсте кандаласы; *русчасы:* **солдатик**

**ЧУА́РЧӘЧӘК** *и. бот.* Лилия

**ЧУА́Р-ЧОБАР** *с.* Бик чуар. *Холкы да җиңел: кыз-кыркынныкыдай чуарчобар, килделе-киттеле.* З.Хөснияр

**ЧУАТ** *и. диал.* Дөя сөтеннән әзерләнгән кымыз

**ЧУВАШ** *и.* Чувашстанда яшәүче, төрки телләрнең берсендә сөйләшүче төп халык һәм шул халыкның бер кешесе. *Җизнәсе калага киткәч, караңгы бер төндә, юлаучы чуваш карчыгы белән чуваш карты бу йортка кунарга төштеләр.* Г.Ибраһимов. *Татар, башкорт, мари, чуваш, удмурт, калмык, казакъ фетнәчеләрен исә бөтен яу барышында, нигездә, старшиналар, тарханнар, солтаннар әйдәп йөри.* В.Имамов

**ЧУВАШОЛОГ** *и.* Чуваш мәдәнияте, тарихы, теле белгече. *Ашмарин Николай Иванович (22.IX.1870 – 26.VIII. 1933) – танылган чувашолог, тюрколог.* А.Тимергалин

**ЧУВА́ШЧА** *рәв.* **1.** 1) Чуваш телендә. *Аннары бер-берсенә шап-шап суктылар, берсен-берсе төртеп-төртеп җибәрделәр, ә Емелькин, чувашча такмак әйтә-әйтә, идән уртасында тыпырдап биергә үк тотынды...* Ә.Еники. *Мин үзем русча укытуга да, чувашча укытуга да каршы түгел.* В.Нуруллин

2) Чувашлар кебек, шулар гадәтенчә. *Өстәвенә әле аның, җирле халык күңелен җилкендереп, татарча һәм чувашча көйли алу сәләте дә ачыла.* Л.Хәмидуллин. *Югыйсә чувашча биегәндә сүтелеп китүләре дә бар бит әле аларның [киндерә очларының].* З.Зәйнуллин

**2.** *с. мәгъ.* Чуваш телендә булган. *Шкафына татарча, төрекчә, гарәпчә, инглизчә, чувашча китаплар тезелгән.* Безнең гәҗит

**3.** *и. мәгъ.* Чуваш теле. *Чит илләрнең шигъри антологияләрен турыдан-туры чувашчага тәрҗемә иттеләр.* Р.Батулла. *Чувашчаны безнең Ренат Харис белән Кави Латыйп су урынына эчә, Шәрәф Мөдәррис тә шундый иде --.* Р.Миңнуллин

**ЧУВА́ШЧАЛАП** *рәв.* Чуваш телендә. *Миклуша хатынына чувашчалап берничә сүз әйтте ---.* Т.Нәбиуллин. *Капитан Бульон миңа берне суккач, мин чувашчалап саный башлаган идем инде.* З.Зәйнуллин

**ЧУЕН** *и.* **1.** 1) Тимер белән углерод (һәм башка элементлар) катнашмасыннан гыйбарәт эретмә. *Имән урманнары өстендә баюга барган кояш, гүя шул агач кәүсәләрен ягып, чуен кайната иде.* А.Хәлим. *Яшь галимнәр чуен өстенә лазер белән чәчәк уялар.* К.Сибгатуллин

2) Мичтә пешерү өчен, шул эретмәдән ясалган тар төпле чүлмәк. *Илсөяр, үз кулы белән тыгылып, чуеннан зур бер бәрәңге алып тоз сипте дә иреннәренә китерде...* Г.Гобәй. *Башта алдыңа бер чуен итле аш куйдык.* А.Хәсәнов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Шул эретмәдән эшләнгән. *Бу киңәшмәгә ай дигәндә, яңа гына сузылган чуен тасмалар буйлап беренче паровоз килде.* А.Алиш. *Бизәкле чуен койма белән әйләндереп алынган болындай зур ихата.* В.Имамов

2) *күч.* Төсе, катылыгы белән чуенга **1.** (*1 мәгъ.*) охшаш. *Син шундый чибәр, күркәм егет. Кулың кайнар, көчле! Күкрәгең тыгыз, иңнәрең чуен.* А.Гыйләҗев.

3) *күч.* Формасы белән чуенга **1.** (*2 мәгъ.*) охшаган. *[Беренче хатын:] Шул китүеннән үзе шикелле үк тәбәнәк, дәү чуен башлы, муенсыз рус егетенә кияүгә чыгып, бергә җайсыз кысылышып төшкән сап-сары фотоларын аналары Зөләйха күрсәтеп йөргән шул.* Д.Салихов

◊ **Чуен кисәге** *к.* **чуенның ундүртенче кичәсе**. **Чуен китеге** *к.* **чуенның ундүртенче кичәсе**. *Өлкәннәр Мансурдан: «Гел менә чуен китеге булдың бит син!» – дип көлә башладылар.* Н.Хәмиди. *Шул кара чуен китегенә Гүзәлияне биреп җибәрәбезмени инде?* М.Әмирханов. **Чуенның ундүртенче кичәсе** Төсе-бите бик кара, кара тутлы кеше. *[Вәли:] Безнең бер асрау бар, йөзе менә нәкъ чуенның ундүртенче*

*кичәсе төсле кап-кара.* Г.Камал. *Ком гарәбенә әйләнгән бу! Күр әле йөзен! Чуенның ундүртенче кичәсе!* Н.Кәримова. **Чуенның ундүртенче кисәге** *к.* **чуенның ундүртенче кичәсе**

**ЧУЕНБАШ** *и.* Бик үк акыллы булмаган кеше. *Әмма ул аягүрә катып калган догматик та түгел, тормышның кимчелекләрен дә күрә белә, җитәкче органнарның начар эшләрен тәнкыйтьтән итүдән дә куркып тормый, бюрократлашып беткән кайбер аңгыра-мокыт түрәләрне ул еш кына чуенбашлар дип атый торган иде.* Ә.Еники

**ЧУЕН ЮЛ** *и. иск. к.* **тимерьюл**. *Авылдан киткәч тә, мин иң элек Мәскәү тирәсендә чуен юлда эшләдем...* М.Галәү. *Алар, составлар үтми-сүтми торган арада, чуен юллар аша аргы якка үттеләр.* А.Хәлим

**ЧУЕ́Н ЮЛЫ** *иск. сөйл. к.* **тимерьюл**. *Менә, менә ансына рәхмәт, чуен юлы китте.* Г.Камал. *Әй, балалар, чуен юлы – бик тынгысыз урын икән ул...* А.Гыйләҗев. *Хәтта әле чуен юлының да салынмаган чагы.* Л.Хәмидуллин

**ЧУЕР** *и. сөйл. к.* **чуерташ**. *Чигенәбез алга таба... Алга таба барган юлга чуер булып ята-ята...* Р.Харис. *Учыбыздагы чуерларны, чиратлашып, идәнгә чәчеп җибәрәбез.* Т.Нурмөхәммәтов

**ЧУЕРЛАНУ** *ф.* Кату; шомару. *Юлдагы балчыклар чуерландылар, көпчәкләрнең шиннары ялтырады.* А.Алиш

**Чуерланып тору** Әле, хәзер чуерлану. *Ул, иләмсез кизәнеп, чуерланып торган ташка кәйләсе белән китереп орды – таш дүрт кисәккә аерылып китте.* Җ.Рәхимов

**ЧУЕРТАШ** *и.* **1.** 1) Су белән юылаюыла шомарган йомры таш; *русчасы:* **галька**. *Әле бетон бутагыч һаман бертуктамый әйләнә, калай труба аша цементка укмашкан чуерташлар коелалар иде...* А.Алиш. *Зур-зур аквариумнарда нинди генә балыклар йөзми, инеш ярындагы чуерташларга кадәр салганнар.* Н.Хәсәнов. *Чуерташ метаморфик, тыгыз һәм суга чыдам утырма тау токымнарын ваклап та җитештерелә.* Төзү материаллары

2) Урамнарга түшәү өчен яисә кайбер биналарны салганда кулланыла торган йомры таш; *русчасы:* **булыжник**. *Бу урамга чуерташ салганнар, йөрүе авыррак*

3) Катып, укмашып хасил булган каты бөтен бер кисәк, монолит. *Борынгы тоз заводлары агызган рассол еллар буе җиргә сеңеп, йомшак балчыкны чуерташка әйләндергән.* Г.Ахунов

**2.** *с. мәгъ. күч.* Шомарган; калыплашкан. *Әмма чуерташ мактаулар өчен дә тәнкыйтьче яшь романчының әсәрен шакмактан шакмакка сүтәргә тиеш иде.* А.Хәлим

**ЧУҖЫК** *и. төрек иск.* Бала. *[Үзенең матурлыгыннан] хәбәрсез гүзәл чуҗык кеби, [сез] кадреңезне [үзегез киметүчеләр].* Г.Тукай

**ЧУК** I *и.* **1.** 1) Нәрсәне дә булса бизәү, матурлау өчен, төрле җеп, тасма, нечкә бау һ.б.ш.дан бер башын төйнәп эшләнгән бәйләм. *Җилбер-җилбер, җилбер чук, аның асты кызыл чук, асылынган, салынган, кызлар шуңа ялынган (кура җиләге).* Табышмак. *--- шунысы кызык: һәр багананың очы гүя киртләп очланган чук белән чукланган иде.* А.Хәлим

2) Нәрсәнең дә булса читендә куе булып урнашкан җеп, тасма, нечкә бау һ.б.ш.дан гыйбарәт буй, чачак. *Җилдә җилфердәгән ефәк шәл чукларыдай, яшь яфраклар арасында иртәнге кояш нурлары уйныйлар.* Г.Кутуй. *Теләсәгез, мендәрчекне чук белән бизәсәгез дә була.* Л.Хаҗиева

3) *диал.* Тукыма кисәге; корама. *Матур чуклар*

4) Конфет кәгазе. *Конфет чуклары җыю*

5) *этн.* Хатын-кызларның муенга киелә торган бизәнү әйбере. *Әмма яка чылбыры бу заманда ташланып бара, яки муенга энҗе чук кияләр.* К.Насыйри

6) Кулның беләзектән алып бармак очларына кадәр булган өлеше. *Хатын, сискәнеп, бөтен гәүдәсе белән талпынып куйды, тез өстендәге кул чуклары гармун теленә баскандай хәрәкәтләнде.* Х.Камалов. *1945 елның сентябрендә унтугыз яшьлек Шәйхелислам абый да, ике күзе дә күрмәс булып, кул чуклары чәрдәкләнеп беткән хәлдә туган йортка кайтып төшә.* Т.Нәҗмиев

7) Бер сабакта яки тармакта бергә җыелып үскән җимешләр яки чәчәкләр; тәлгәш. *Менә бу каен чугы өстенә басылган текстны укуы авыр, диде Галимҗан да, үз бүлегеннән киткән шигырьне кайгыртып.* Л.Ихсанова. *Чәчәкләре өзлекле яки сирәк башаксыман чук хасил итәләр.* Агулы үсемлекләр

**2.** *с. мәгъ.* 1) *бот.* Бик тармакланган (үсемлек тамыры тур.). *Өч җәймәле эт тигәнәге (череда трёхраздельная ---) – кыска чук тамырлы, 15–100 см биеклектәге, күп очракта өске өлеше нык тармакланган дүрткырлы сабаклы берьеллык үләнчел үсемлек.* Агулы үсемлекләр

2) *күч.* Матур. *Синең әле чәчәк чагың, чук чагың, ялкын чагың, ут чагың.* Ф.Яруллин

◊ **Чук кебек** Бик яхшы; бик матур; бик җитеш. *Аларча, шагыйрьгә кияүгә чыккан кеше чук кебек киенергә тиештер инде.* Л.Ихсанова. *Инде бөтен җире чук кебек булган, шуның белән туктар дисең, юк, туктамый, янә бернәрсә уйлап таба.* Ф.Яруллин. *Клубта кызлар күп, чук кебек киенгән ике шәһәр кызы бар иде ---.* Г.Якупова

**ЧУК** II *с. иск.* Күп. *Хөрмәтле Салих әфәндегә чук сәлам, безләр сәламәтләрбез.* Ш.Мөхәммәдев. *Илеңез имин улсын, терлек-туарыңыз чук улсын.* Н.Фәттах

**2.** *рәв. мәгъ.* Бик. *«Шәркы рус»ның иң кирәкле бер көндә сүнеп киткәненә чук үкенәмез.* Г.Камал

**ЧУ́ККАНАТЛЫ** *с. зоол.* Йөзгечләре кул чугына охшаш (балыклар тур.). *Якынча 400 млн ел элек безнең планетаның диңгезләрендә һәм төче сулыкларында чукканатлы балыклар барлыкка килгән.* Биология. Хайваннар

**ЧУККОЙРЫК** *и. зоол.* Саргылт төстәге буынтык-буынтык гәүдәсенең ахырында чуктай төкләре булган пар аяклы күбаяк; *русчасы:* **кистехвост**

**ЧУКЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **чуклау** (*1 мәгъ.*). *Куе яшькелт арыш төбендә юл-юл булып чәчкеч эзләре сузылган, төбеннән саргая башлаган арыш куе рәт, дивар булып кайшалып үсеп киткән, һәм аның тыгыз башаклары сөтле-баллы орлыклар белән авырайган, арыш чәчәге-серкәсе белән чукланган иде.* М.Мәһдиев. *Аның кулында – ал, сары, зәңгәр ефәкләр белән чукланган зур гына ак кулъяулык.* Н.Яһудин

2) Чук рәвешен алу. *Савытның тирәнлеге 10 см булса әйбәт, кәбестә үсентеләре иркенләп, тамырлары чукланып үсә, күчереп утырткач, тиз тернәкләнә.* Безнең гәҗит

**Чуклана башлау** Чуклану билгеләре күренү. *Теге кичне Рәсимәнең чабата башы чуклана башлаганын күреп, төне буена керфек тә какмыйча чабата үрдем.* Г.Галиев. *Тузудан чуклана башлаган ыштан балагы эченнән чыгып торган тәпие, кутыр-чатыр чебиләп, тәмам каешланып каткан иде.* М.Хәсәнов

**Чукланып бетү** Бик чуклану. *Өстендә тересәкләре бәсәреп, итәкләре чукланып беткән чапан, аякларында авызын ачкан кәвеш.* В.Имамов. *Чалбар*

*балаклары пычранып, тузып, чукланып беткән, күлмәгенең нинди төстә булуын да әйтеп булмый.* Г.Гыйльманов

**Чукланып тору** Әле, хәзер чукланган хәлдә булу. *Бау төрле төстәге ефәк җепләр белән ишелгән, оч-очлары төйнәлгән һәм чукланып тора иде.* М.Хәбибуллин

**ЧУКЛАП** *рәв.* Матурлап, бизәп; артык чуарлап. *Ә татар укучысы тасвирлауларны, табигать күренешләрен чуклап язуны бик өнәп бетерми. Ул мәйдандагы уеннарны җанландыра белә, кызык-мызыклар белән чуклап сөйләве дә тамашага күңеллелек өсти.* Әлки хәбәрләре

**ЧУКЛА́П-ЧАЧАКЛАП** *рәв. к.* **чачаклап-чуклап**. *Юлтай аның белән шулай ук, Бохарадагы йола буенча, чуклап-чачаклап исәнләште һәм хуҗаның, аның гаиләсенең сәламәтлеген, мал-мөлкәтенең иминлеген сорашты.* Т.Әйди

**ЧУКЛА́У** *ф.* 1) Чук (*1 мәгъ.*) белән бизәү, чук тагу. *Мин аларның сугышка хәтле нинди булганын беләм: җиз төймәләр белән бизәп, чуклап эшләнә иде.* Ш.Галиев. *Бишбалтада ясалган тарантаслар белән бергә көмеш тәңкәләр тезеп, чуклап ясаган дирбияләрне бөтен Идел буеннан, хәтта Мәскәү кадәр Мәскәүдән килеп алып китә торган булганнар.* Р.Ибраһимов

2) Чуксыман итү. *Тик агач шәүләсе яр буен чуклаган.* Н.Исәнбәт

**Чуклап кую** Тиз генә чуклау. *Чит-читләрен чуклап та куйсаң була әле.* Сөембикә

**ЧУКЛЫ** *с.* **1.** 1) Чук (*1 мәгъ.*) тагылган. *Чалбар балагын чыгарып салыр идем дә, билне чуклы зәңгәр зәр белән буып, кызлы йортка барып керер идем.* А.Гыйләҗев. *Мөхәммәт чуклы пумала белән куган сине.* В.Имамов

2) Чит-читләренә чук (*2 мәгъ.*), чачак тотылган. *Әби башына чуклы ефәк шәл бәйләп, билле бәрхет камзул кигән, аягында бизәкле кызыл читек иде.* А.Тимергалин. *Менә сиңа нинди матур атлас күлмәклек, әле тагын озын чуклы ефәк шәл апкайткан.* Г.Галиева

3) *бот.* Чәчәкләре чуксыман булган. *Шаулый иген уңда, сулда. Юл читендә – чуклы үлән.* Р.Низамиев. *Татарстанда үсә торган төрләре: саз сөтлегәне (молочай болотный ---); чуклы сөтлегән (молочай полумохнатый) ---.* Агулы үсемлекләр

4) Тышкы күренеше чукны хәтерләткән. *Манара биеклеген куып җитәргә теләгәндәй сузылып үскән тупылның шәмәхә чуклы, хуш исле ябалдашыннан сузып-сузып аваз салгалаучы төнге кош кисәк тынасы итте.* Л.Зөлкарнәй

5) Кәгазьгә төрелгән, кәгазьле (конфет һ.б.ш. тур.). *Менә шул чакта кияү үзенең эчке кесәләрен актарды, матур буяулы кәгазьдә исле сабын, яшькелт төсле ислемай, кечкенә кызыл тартмада иннек, кершән, тагын кызыл кәгазьле, озын чуклы, озын, йомшак, тәмле конфетлар чыгарды.* Г.Ибраһимов

6) *күч.* Тышкы бизәкләре күп булган; төче. *Кода үзенчә философ, психолог булып чыкты – фикере нинди шәрехле, сүзләре нинди чуклы!..* Р.Харис. *Зөбәйдә, егетнең чуклы сүзләренә ышанып, мәкергә юлыга ---.* К.Гыйззәтов

**2.** *с. мәгъ. физ.* Очкыннар электродлар арасында тоташ чук тәшкил итә торган. *Чуклы бушану*

**ЧУКЛЫ́Й-ЧУКЛЫЙ** *рәв.* Бик матурлап, бизәкләп; матур сүзләр сайлап. *Гаффә мине үлеп яратуы турында чуклый-чуклый яза.* Х.Камалов

**ЧУКМАР** *и.* **1.** 1) *тар.* Борынгы халыкларда сугышу коралы буларак кулланылган бер башы йомры кыска авыр күсәк. *Сөңге, чукмар тотып атка менгән ир-егетләр үзләренең яралы тәннәрен дошман гәүдәләре белән күмгәннәр.* А.Гыйләҗев. *Кеше борынгыдан ук ташны үз файдасына җиккән, аңардан кыргычлар, пычаклар, ук-сөңге очлары, бәргеч кораллар, чукмарлар ясаган.* А.Тимергалин

2) Гадәттә резиннан эшләнгән авыр күсәк рәвешендәге, хокук саклау органнары хезмәткәрләре кулланган корал төре. *Башларында тимер каска, билләрендә пистолет, кулларында резин чукмар...* М.Юныс

3) Нәрсәнең дә булса йомры башы. *Ул аяк-кулларын кура җиләге куаклары сыдырта-сыдырта, тигәнәк чукмарларына сарылып бетеп, атау читеннән әйләнде һәм лапас янына килеп туктады.* Р.Вәлиев. *Микрофонның чукмары зур булмасын иде.* К.Сатиев

4) *күч.* Тәэсир көче зур булган нәрсә. *Ләкин бу очракта мин аның белән тартыша алмыйм, чөнки аның кулында власть дигән авыр чукмары бар.* В.Нуруллин

**2.** *с. мәгъ.* Бер башы йомры булган, йомры башлы. *Кәкре борынлы Козгын Әхмәтенең чапаны астыннан чукмар башлы бизмән тимере тырпаеп тора.* М.Хәсәнов. *Китапханә хадимәсе, өенә кайтырга талпынып, бер – аның иелгән киң җилкәсенә, бер дивардагы шакмаклы кара рам читләгән сәгатьнең өнсезтавышсыз шуышкан чукмар телләренә карап-карап куядыр.* А.Гыйләҗев

◊ **Чукмарның авыр башы** *к.* **таякның авыр башы**. *Тимер чукмарның иң авыр башы Тинчурин җилкәсенә килеп төште.* Р.Низамиев

**ЧУКМАРБАШ** *и.* Кайбер җир-су хайваннарының (мәс., баканың, гөберле баканың һ.б.ш.) уылдыктан барлыкка килгән баласы. *Җәй көннәрендә авыл малайлары белән елгада чукмарбашлар тотты, су коенды, тәне каралып пешкән чия төсенә кергәнче кояшта йөрде [Рөстәм.]* Ф.Яруллин. *Сез рәсемдә чукмарбашның ничек бакага әверелүен күрәсез.* Биология

**ЧУКМАРЛА́У** *ф.* 1) Чукмар белән кыйнау. *Куыгыз чукмарлап ахырзаман галәмәтен!* М.Рафиков. *Милиция безне чукмарлап куды.* М.Юныс

2) *күч. сөйл.* Тәнкыйть итү, фаш итү. *Бик үткен журнал тарала: Исме ничек? «Уклар»мы? Иске-москы муллаларны Һич кызганмый чукмарлый.* Г.Тукай

**ЧУКМАРЛЫ** *с.* Бер башы йомры; чукмары булган. *Ул, һичбер нәрсәгә илтифат итмичә, сан алу карточкаларын чыгарып, беренче туры килгән кеше турында белешмә яза башлаган иде, баш өстендә чукмарлы күсәкләр, йомарланган йодрыклар уйный башлаганны күргәч, шурләде ---.* М.Галәү. *Чукмарлы күсәк атның күкрәгенә килеп тиде.* Н.Фәттах

**ЧУКМАР СӨЯК** *и. анат.* Бот сөягенең шарсыман калынаеп торган югары өлеше

**ЧУКРАК** *с.* **1.** 1) Бөтенләй ишетми яки бик начар ишетә торган; саңгырау. *Сукыр һәм чукрак батырны карлик та җиңә.* Г.Әпсәләмов. *Әйтерсең без югары оч чукрак Зиннур белән китеп барабыз.* Л.Хәмидуллин

2) *күч.* Суы акмый торган. *Чукрак буа*

**2.** *и. мәгъ.* Ишетми яки начар ишетүче, саңгырау кеше. *--- әллә җыен чукрак җыелган инде монда?..* Г.Бәширов

**ЧУКРА́К ГӨМБӘ** *и.* Шампиньончалар семьялыгыннан кипкәннән соң эче кара көрән тузанга әйләнә торган шарсыман гөмбә (ышануларга караганда бу тузан кешенең колагына керсә, аны чукраклandырырга мөмкин); куык гөмбә

**ЧУКРАКЛАНДЫРУ** *ф.* Чукракка әйләндерү, ишетмәс хәлгә китерү. *Мәхәббәт акылны ала бит ул, күзне сукырайта, чукракландыра.* М.Әмирханов

**ЧУКРАКЛАНУ** *ф.* Чукракка әйләнү, ишетмәс булу. *Әгәр хәзер трубканы ташламаса, аның колаклары чукракланыр күк.* Р.Вәлиев. *Рабига ике атна буе тынлыкта яшәп чукракланган иде.* Н.Гыйматдинова

**Чукракланып бару** Акрынлап, торабара чукраклану. *Әти, син әллә чынлап чукракланып барасыңмы?* А.Хәсәнов

**Чукракланып бетү** Тәмам чукраклану. *Югыйсә тып-тын бүлмәләрдә йөри-йөри чукракланып беттем инде.* Г.Әпсәләмов. *Алтын балкышыннан авыл тәмам сукыраеп, чукракланып беткән иде инде.* Г.Гыйльманов

**Чукракланып калу** Берәр сәбәптән, вакыттан чукраклану. *Әллә бераз чукракланып калганмы?* Ә.Еники

**ЧУКРАКЛЫК** *и.* Чукрак булу үзлеге; саңгыраулык. *Кичен Копылёвны хөрмәтләп җырладеләр, ә Мирхәйдәров санбатта бер-ике көн булды да кире кайтты, чөнки, чукраклыгың вакытлыча, колагың ачылыр, диделәр.* З.Мурсиев. *Аяк очына гына басып, шауламаска тырышып өеннән чыкты, югыйсә хатыны барыбер ишетмәс иде – ул инде биш-алты ел чукраклыгыннан зарлана ---.* Р.Зәйдулла

**ЧУКРА́К-ТЕЛСЕЗ** *с.* **1.** Бөтенләй ишетми торган һәм сөйләү сәләте булмаган. *Чукрак-телсез булгач, исән чагында да тып-тын яшәде...* З.Хәким. *Чукрак-телсез булуы аркасында гына аңа яр булган, сөеп туйгысыз гүзәл Гамиләсе белән бәхетле иде ул.* М.Садыйков

**2.** *и. мәгъ.* Ишетми торган һәм сөйләү сәләте булмаган кеше. *Официантлар, пешекчеләр, чукрак-телсезләр шикелле, авызларыннан сүз чыкса да, «әйе», «юк»тан башканы белмиләр иде.* Ә.Хәсәнов. *Милләтен ничек белдерә ләкин чукрак-телсезләр?* Р.Харис

**ЧУКТАМЫР** *и. бот.* Үзәк тамыры булмаган, бик нечкә тамырчалар булып тармакланган тамыр. *Гадәттә, ул юан гына үзәк тамыр һәм чуктамырлардан торган шактый гына зур мунчаладан гыйбарәт.* Сөембикә

**ЧУКУ** *ф.* 1) Азыкны томшык белән эләктереп алып ашау (кошлар тур.). *Ә үрдәкләр, ә казлар Көн дә үлән чукыйлар.* Р.Миңнуллин

2) Томшык белән эләктереп алу, томшык белән чокып, тартып чыгару. *Илсөярнең баш очында гына тырышыптырышып агач чукып маташкан кызгылт түшле тукран, чукуыннан туктап, акыллы күзләре белән аска карады.* Г.Гобәй. *Мирвәлине күргәч, канатларын җилпеп-җилпеп, су өстеннән йөгереп килгән үрдәкләр аның кулларын, тәнен чукып кытыклый башлагач кына, бу дөньяның чынлыгына ышанып, көлепелмаеп җибәрде ул.* Г.Гыйльманов

3) *диал.* Чоку, казу. *Вакыйган бу – вак сәнгатьчеләрнең вә фөкараның урамы иде; чөнки тагы бер өй алдында берәүнең, бик азапланып, таш чукып кабер ташы язып утырганын күрде ---.* Г.Гобәйдуллин. *КП дүрт яктан таулар белән чолганып алынган үзәнлекнең көньяк почмагында, текә тау итәгенә чукып эшләнгән землянкада иде.* Г.Әпсәләмов

4) Ачудан, җәзалау йөзеннән берәр кешенең күз алмаларын чокырларыннан алу. *– Бәйлән генә, күзеңне чукыйм! – дип гайрәтләнде кыз, ә үзенең йөрәге дөп тә дөп сикерә иде.* Н.Гыйматдинова. *Күзен чукырдай, якасына ябышырдай булдым тегенең.* Р.Зарипов

5) *күч.* Бәйләнү; җәберләү; гаепле итеп күрсәтү. *Мине виноват ясамакчы буласызмы әллә? Нигә бергәләшеп мине чукыйсыз?* А.Гыйләҗев. *Карале, Халдә, нишләп син мине чукыйсың да чукыйсың?* Н.Гыйматдинова

6) *күч.* Җентекләп өйрәнү. *Миңа синә мә, дим мин, һаман унтугызынчы гасырны чукыйлар икән әле болар.* Г.Афзал

◊ **Чукырга гына тору** Җае чыккан саен җәберсетү, бәйләнеп тору. *Әни, син гайбәтләргә ышанасың, Фаязны чукырга гына торасың.* Х.Камалов

**Чукый башлау** Чукырга тотыну. *Әллә баягы, әллә бүтән бер тукран якында гына, тук-тук итеп, агач чукый башлады.* Г.Гобәй. *Берзаманны, һәр кич саен, әллә нинди гриф дигән явыз кошлар килеп, моның күкрәген тишкәли, йөрәген кисәк-кисәк итеп чукый башлаганнар.* В.Имамов

**Чукый бирү** Бернигә карамый чуку. *Сарай эченә кереп, бер урыннан икенче урынга канатларын кагып тыпырчынды һәм утыннар арасында кадакта эленеп торган әтинең иске, соры кәчтүменә очып кунды да, үткен, нык томшыкларын ошбу киемгә ышкып, әтинең кәчтүмен чукый бирде.* Казан утлары

**Чукый тору** Кат-кат, озаклап чуку. *Шулай итеп, бик чукый торгач, инде канат каурыйлары ныгый башлаган, ашарга өйрәнгән бер бәпкәсен чукып үтерде бит!* Н.Кәримова. *Чукый торгач, ниндидер кеше сурәте туа башлый.* К.Җәмит

**Чукып алу** Тиз генә, кинәт чуку. *Ул да булмый, әлеге шул өч-дүрт күкәйдән үтә тере, үтә үткен, үтә усал, бармагыңны оя авызына китерсәң, шунда ук чукып алырга әзер чебешләр – сыерчык балалары чыга.* А.Хәсәнов. *Каз, башын бер яктан бер якка салгалап, теге таныш түгел нәрсәләргә карап торды да тагын чукып алды.* Аманулла

**Чукып ату** *к.* **чукып ташлау**. *– Хәзерге заман кешесен белмәссең, – дип сөйләнде ул, – бөркетне тавык чукып атырга да мөмкин.* Ф.Яруллин

**Чукып бетерү** Тулысынча чуку, бик нык чуку; төрле җирдән чуку. *– Нигә аз алып килдегез, шуның өчен үзегезне чукып бетерәбез, – дигән кебек, Мирвәли белән Гаделгә ябырылдылар.* Г.Гыйльманов. --- *Мин византиялеләргә ышанмыйм, ялганлаганың өчен, мин сине казыкка утыртыр идем, кошлар чукып бетергәнче торыр идең шунда.* М.Хәбибуллин

**Чукып йөрү** Даими, озак вакытлар чуку. *Кешеләр генә түгел, кошлар да Тук булырлар, чукып йөрерләр.* А.Нәҗми

**Чукып кую** Бер тапкыр чуку. *Башын кыегайтып карый, тәрәзә пыяласын чукып куя, күзгә карап көтә.* Ш.Галиев. *Башта түп-түгәрәк итеп йөзен ясый, аннары күз-борынын чукып куя.* К.Җәмит

**Чукып ташлау** Бик тиз арада чуку. *Монда ниндидер козгыннар җыелган, чукып ташлаулары бар.* Н.Фәттах. *– Карга сыман каркылдап, ил өстенә яңа тилгән чакырмасак ярый да бит үзе! – дип, бер саграк ир җим ташлаган иде, аны ярсу әтәч сыман чукып ташладылар.* В.Имамов

**Чукып тору** Бертуктаусыз, әледәнәле чуку; әле, хәзер чуку. *Кызыл әтәч гел чукып торды аны, шуңа рәте юктыр.* Ф.Яруллин. *Аларны хәтта үз ишләре читкә этә, җәй килгән саен чукып тора.* Р.Габделхакова

**ЧУ́КЧА** *и.* Чукотканың төп халык атамасы һәм шул халыкның бер кешесе. *Алты ай кояш күренмәгән салкын якларда да яшәп ята бит чукча, ненецлар.* А.Гыйләҗев. *Чукчалар һәм эскимослар сәнгатендә сөяккә уеп эшләнгән әйберләр өстенлек итә.* К.Гыйззәтов

**ЧУ́КЧАЧА** *рәв.* **1.** 1) Чукча телендә. *Чукчача сөйләшү*

2) Чукчалар кебек, шулар гадәтенчә. *Чукчача киенү*

**2.** *с. мәгъ.* Чукча телендә булган

**3.** *и. мәгъ.* Чукча теле

**ЧУ́К-ЧУК** I *ы.* Дуңгызны чакыру сүзе; чүк-чүк

**ЧУ́К-ЧУК** II *иярт.* Төрле кошлар сайраган тавышны белдерә; чут-чут

**ЧУ́К-ЧУК ИТҮ** *ф.* Чук-чук килгән тавыш чыгару. *Бервакыт чук-чук итеп сайрый Ходайның кошлары.* Г.Тукай

**ЧУКЫЛДАШУ** *ф. сөйл. к.* **чукырдашу**. *Кызлар аңа һич игътибар итмичә, берсен берсе бүлдерә-бүлдерә, чәүкә балалары сыман чукылдашырга тотындылар.* Г.Бәширов

**ЧУКЫНГАН** *с.* **1.** 1) Христиан динен кабул иткән

2) *күч. гади с.* Бик булдыклы. *Чукынган гына хатын икәнсең, билләһи!* В.Нуруллин

3) *күч. гади с.* Начар, әшәке дип табылган. *[Әбузәр:] Әй, ул чукынган халык белән эшләп буламы.* Т.Гыйззәт. *Кичен көтү кайта: – Кер әйдә, чукынган хайван!* Р.Батулла

**2.** *и. мәгъ. гади с.* Берәр кеше тарафыннан тискәре яки уңай бәя алган яисә шаяртып характерланган һәртөрле җанлы-җансыз. *[Нәгыйм хәлфә:] Ну соң, чукынганның кулы йомшак икән, торып китә башлагач, эләктереп алган идем, кулым май кебек булып эреп китте.* М.Гафури

**3.** *ы. мәгъ. гади с. к.* **чукынчык**. *Отпускага кайткан майор белән Ирен ташлап качты, чукынган...* Г.Афзал. *Чәчәген дә алыр идем, Кыйбат икән, чукынган.* Л.Шәех

**ЧУКЫНГЫРЫ** *и. гади с. к.* **чукынган**. *Ник дисәң, иң кирәкмәгән чакта килеп керә бит ул берәр чукынгыры.* К.Кара

**ЧУКЫНДЫРУ** *ф.* **1.** 1) *йөкл. юн. к.* **чукыну** (*1 мәгъ.*). *Моның өчен кирәк булса, я үзе мөселманлыкка чыгар, я мине чукындырырга теләр.* Г.Ибраһимов. *Сөембикәнең Үтәмеш атлы улын урыс кенәзләре көчләп чукындырган.* В.Имамов

2) Христианнарда яңа туган баланы рәсми рәвештә христиан диненә кабул итү йоласын башкару. *Җитмәсә, кодагый тиешле кеше балаларны чиркәүгә алып барып, икесен дә чукындырган.* И.Нәбиуллина

3) *күч. гади с.* Үтерү, дөмектерү; юкка чыгару. *«Ялт-Йолт» та юк, «Яшен» дә юк Мәкәрҗәдә, шул тыятырны гына чукындырасы бар!* И.Юзеев. *Нурулланың авыз колакта иде: «Чукындырдык теге мөртәтне!» – диде ул, Исхакны күргәч.* А.Гыйләҗев // Кыйнау. *Халәп кебек ата ялкауны, йодрык белән чукындырсаң да, эшләтеп булмаячак.* М.Хәсәнов

4) *күч.* Сәламәтлеккә зур зыян салу. *Шул моменттамы, алты тәүлек буенамы, безне радиация чукындырган.* Х.Камалов

5) *күч. гади с.* Кирәген бирү, күрмәгәнен күрсәтү; көлкегә калдыру, *[Гәрәй:] Чукындырды. – Чеметеп-чеметеп алдымы?* М.Фәйзи. *Ну, мәйтәм, бер чукындырам әле мин сине, дим, бүлмәдә үзем генә калгач.* Н.Хәсәнов

**2.** *ы. мәгъ.* **чукындырасыңмы** «Берни эшләтеп булмый» мәгънәсендә кулланыла. *Талант инде, чукындырасыңмыни аны!* Р.Миңнуллин

**Чукындыра башлау** Чукындырырга керешү. *Әллә... мин әйтәм... чукындыра башласалар, ризалашкан булып кыланыйкмы?* С.Зыялы

**Чукындыра килү** Әлегәчә эзлекле рәвештә чукындыру. *Олегның этисе, үз вазифаларына тугры калып, Коногоровкада гына түгел, күрше-тирәдәге авылларда туган һәр баланы чукындыра килгән.* А.Хәсәнов

**Чукындырып бетерү** Барысын да чукындыру. *Мәгәр аларның һәммәсен дә Иван, Николай, Маруся дип чукындырып бетергәннәр икән шул...* В.Имамов

**Чукындырып кую** Тиз генә, хәзер үк чукындыру. *Попларыгыз булса, әйдә, хәзер үк чукындырыйк та куйыйк.* В.Имамов

**Чукындырып ташлау** Бик тиз арада чукындыру. *Шуннан соң, византияле принцесса Аннага өйләнү бәрабәренә, бөтен Русьны чукындырып ташлый.* З.Хөснияр

**Чукындырып тору** Әле чукындыру. *Әйе, дөрест, шулай булды: ул Аннаны чиркәүдән чыкканын күрде, балаларын – үз балаларын чукындырып торганда очратты.* Г.Исхакый

**ЧУКЫНМЫШ** *и. гади с. к.* **чукынчык**. *Шәп бии икән, чукынмыш!* В.Нуруллин. *Шәкүр караклар, аннары Ермак һәм Ермолов кебек нәселләрен саткан чукынмышлар...* А.Тимергалин

**ЧУКЫНУ** *ф.* **1.** 1) Чумылдыру йоласын үтәп, христиан динен кабул итү. *Византия йогынтысында алар да чукына.* Т.Әйди. *Я хәзер үк чукынасың да христианлыкка күчәсең, я, корабтан төшеп тә тормыйча, кире борылабыз!* В.Имамов

2) Уң кул хәрәкәте белән христиан диненең символы – тәре билгесен ясау. *Менә ул кат-кат тырышып чукынды да түшәгенә ятты.* В.Имамов. *Саша да әти-әнисенең кабере өстендә чукынып баш ия.* З.Кадыйрова

3) *сөйл.* Христианнарда гыйбадәт кылу. *Яшь чагында Марфасы белән икәү чиркәүдә чукынганнарын үз күзләрем белән күрә идем.* Н.Гыйматдинова

4) *күч. сөйл.* Баш ию, табыну. *[Хәким:] Гомерем буе акчага чукындым.* Г.Каюмов. *Шул укуыңа чукынып гомерең үткәндер...* Г.Гыйльманов

5) *күч. гади с.* Бетү, юкка чыгу; дөмегү. *Давыд кул селекте, чукынсын ла, кырык биш булмагае, йөз дә биш булсын, баласы, миңа дисә, ун булсын, безгә әһәмият анда түгел.* Г.Ибраһимов. *Берәү булса, кайнанасының мондый тилелеген күреп: «Чукын шунда, карт тәре!» – дип шатланыр гына иде.* З.Хөснияр // Әрәм булу. *Мөҗидә, Мөҗидә, аяк чал, аяк чал Гимадиягә, түгелсен, чукынсын сөте!* А.Хәмзин

6) *күч. гади с.* Эш бозылу, кире китү, барып чыкмау. *Язгы урамны күрдем дә Йөрәк тагын чукынды.* И.Сабиров // Үзәккә үтү, меңгә төрләнеп алҗыту. *– Чистый чукынды бу дөнья, муллаңны силсәвиткә чакыртасы! – диде ул, ярсып.* В.Имамов

**2.** *ы. функ. гади с.* 1) **чукын, чукынсын, чукынды** Үкенеч, кызгану, ризасызлык һ.б.ш. хисләрне белдерү өчен кулланыла. *– Чукын инде алайса, әйдә, синеңчә булсын! – диде.* В.Нуруллин. *[Сәйфетдин:] Чукынды, мин әйтәм, тереләй күмәләр икән.* Д.Салихов

2) **чукынсын** «Нәрсә булса – шул булыр» дигән мәгънәдә кулланыла. *Әмир мәетенең үләксә кисәкләрен тәндә йөртеп булмас, әйдә, чукынсын, Торна күленә илтик...* В.Имамов

3) **чукынды** «Эш бозылды», «план җимерелде», «барып чыкмады», «мәсьәлә килеп чыкты» дигән мәгънәдә, ис китүне, канәгатьсезлекне белдерү өчен кулланыла. *Чукынды, хатын, тот кәҗәне ---.* К.Тинчурин. *Чукынды, нәрсә яна икән?* В.Имамов

4) **чукынгыры** Канәгатьсезлекне, үкенечне, соклануны һ.б.ш. хисләрне белдерү яки явыз теләк теләү өчен кулланыла. *Әйтмә дә генә инде!.. Вәт кырык кат чукынгыры.* А.Гыйләҗев. *Барыбер дөнья матур, чукынгыры!* З.Хәким

5) **чукынып** Яратмау, кабул итмәү, канәгатьсезлекне һ.б.ш. хисләрне белдерә. *[Гатау:] Туры килми шул. Чукынып, Гөлйөзем чыгам диде бит бүген.* М.Фәйзи. *[Саймә:] Тыңламады, тыңламады, чукынып, үз башына.* Г.Каюмов

◊ **Чукынды маржа калачка** *к.* **чукыну** (*6 мәгъ.*). *[Бәйрәмгали:] Чукын-*

*ды марҗа калачка! Имәндә икән чикләвек!* Д.Салихов. **Чукынды марҗа кыярга** *к.* **чукыну** (*6 мәгъ.*). *[Рахмай:] Чукынды марҗа кыярга! Мин эш турында сөйләшергә ниятләгәндә генә...* А.Гыйләҗев. **Чукынса да** Беркайчан да, һич. *Гаделҗан мондый чәчәкләрне, чукынса да, акча түләп, базардан хатынына алып кайтып бирмәс иде.* Д.Гыйсметдин. *Ияреп бара ул, ә менә үзен генә чукынсаң да йомышка җибәреп булмый.* К.Булатова. **Чукынса чукына** *к.* **чукынса да**. *Чукынса чукына, ләкин бирми.* В.Нуруллин. *Чукынсам чукынам, шул хәерчеләргә кызымны бирәсем юк, дип әйткән, диме шунда...* Л.Лерон. **Чукынып бет** *гади с.* Каргап яки явыз теләк теләп әйтелә торган сүз. *Чукынып кына бет, хаҗәтемә кирәгең юк, ди.* Ш.Камал. **Чукынып бетсен** Ис китмәүне белдерә. *Каласы чукынып бетсен, заводның муены астына килсен, Садыйгы да йөзтүбән кадалсын.* Г.Ибраһимов. **Чукынып йөрү** Озак вакыт яисә бушка йөрү. *Син кайда чукынып йөрисең?* З.Мурсиев. **Чукынып кит** *к.* **чукынып бет**. *– Чукынып кит кәнтәең белән! – дип, Тахура да күзләреннән очкыннар чәчте.* И.Хәйруллин. **Чукынып китим** Нәрсәнең дә булса дөреслегенә яки тормышка ашырлык булуына ышандыру йөзеннән ант итүне белдерә. *Чукыныплар китим, булдырам бу эшне!* Р.Мингалим. *Чукынып китим, хисләрем саф, ихлас...* Р.Гаташ. **Чукынып китсен** *к.* **чукынып бетсен**. *Чукынып китсен фән, чәнчелеп китсен завод, челпәрәмә килсен эшкә ашмас хыяллар!* А.Гыйләҗев. *– Чукынып китсенсәнә бакчасы, яшелчәсе! – ди бу.* А.Хәсәнов. **Чукынып үлим** *к.* **чукынып китим**. *Валлаһи, баскан җиремдә чукынып үлим, җитди итеп әйтә.* Р.Кәрами

**Чукына башлау** Чукынырга тотыну. *Ул да Шәмси күрмәгәндә чиркәүләргә бара, чукына башлады.* Г.Исхакый. *Хаҗи янында, окоп эчендә басып торган Калиновка чувашы чукына ук башлады.* З.Зәйнуллин

**Чукынып алу** Тиз арада чукыну. *Серебряков ирексездән чукынып алды ---.* Т.Галиуллин. *Игътибарын стенага беркетелгән изге сурәткә юнәлтеп, бертын басып торганнан соң, ул авыз эченнән нидер пышылдап, берничә кат чукынып алды.* А.Мансуров

**Чукынып бетү** Барысы да чукыну. *Без – туганнар, ә аланнар белән чиркәсләр – иманнарын Христоска саткан, чукынып беткән халык.* В.Имамов

**Чукынып җибәрү** Сизмәстән чукынып кую. *Шунда берочтан чукынып та җибәрә күрмәгез тагын!* Р.Юныс

**Чукынып калу** Чукынырга өлгерү. *– Эй, русиш, чукынып калыгыз, соңгы сәгатегез килде, өтәбез! – дип кычкырдылар, янә рус телен вата-җимерә.* Ә.Әминев

**Чукынып кую** Тиз генә чукыну. *Андрей түр почмакта торган иконага карап чукынып куйды ---.* В.Имамов. *Хаким, тәшвишләнеп, чукынып куйды.* З.Мәхмүди

**Чукынып тору** Әле чукыну. *Караңгырак өй эче, кара яулык бәйләгән, кара кофта, кара бөрмәле итәк кигән таза гәүдәле әби почмакка карап чукынып тора ---.* Безнең гәҗит

**Чукынып яту** *сөйл. к.* **чукынып тору**. *Ул мал дип чукынып ята, кулаягы гер асылган я богау салынгандай була.* В.Имамов

**ЧУКЫНЧЫК** *и.* **1.** 1) *сөйл.* Башка диннән христиан диненә күчкән кеше. *Ул, урыс башы белән, мөселман көйләрен ничек белә икән? Әллә чукынчыкмы икән?* Г.Ибраһимов

2) *күч. гади с.* Тиргәү, шелтәләү яисә шаярту сүзе буларак кулланыла. *Шул зимагур гына чәлдереп чыккан икесен, вәт чукынчык!* В.Имамов. *Туктале, кайдадыр күргәнем бар кебек бу чукынчыкны...* Л.Лерон. *Чибәр, чукынчык!* А.Гыймадиев

**2.** *с мәгъ.* Башка диннән христиан диненә күчкән. *Мәхәллә имамы Садыйк мулла исә һәммә кешедән артык курыккан: бу түрә башка берничә мулланың арт сабагын укыткан булганга, иттифакый уларак, күптән түгел бер чукынчык татарга кабат исламга кайту хакында юл күрсәткәнгә, шул мәсьәләне тикшерү өчен килмәдеме икән дип, йөрәге тәмам урыныннан кузгалган вә йөзе агарган иде.* Г.Ибраһимов

**ЧУКЫР** I *и. зоол.* Тау чыпчыклары семьялыгыннан кәкре томшыклы зур булмаган урман кошы; *русчасы:* **клёст**. *Үтеп барышлый, алар янына чукыр да килеп кунды.* К.Тәхау. *Әнә наратлар арасыннан кәкре коңгырт томшыклы, яшел төймә күзле, җирән түшле чукыр очып чыкты.* Ф.Җамалетдинова

**ЧУКЫР** II *и.* 1) *к.* **севрюга**. *Балык шулпасы хәзерләү өчен, диңгез балыкларыннан кырпы, чукыр, осетрина алына.* Ю.Әхмәтҗанов

2) Диңгез алабугаларыннан аскы казналыгы алгарак чыгып торган балык; *русчасы:* **клювач**

**ЧУКЫРДА́У** *ф.* Чукыр-чукыр иткән өзек-өзек тавышлар чыгару (кайбер кошлар тур.).

**ЧУКЫРДАШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **чукырдау**. *Анда-санда мал-туар утлап йөри, кош-кортлар чукырдаша.* И.Хуҗин

2) *сөйл.* Матур гына, йомшак кына сөйләшү; чөкердәшү. *Әйдә, чәй янында чукырдашыйк булмаса.* С.Шәкүров

**ЧУКЫРДАШЫП** *рәв. к.* **чөкердәшеп**. *Кая, чукырдашып, гаилә тормышы белән яшәү?!* Г.Ибраһимов

**ЧУКЫ́Р-ЧУКЫР** *иярт.* **1.** Кайбер кошларның кычкыру тавышын белдерә

**2.** *рәв. мәгъ.* Йомшак кына итеп (үзара сөйләшү тур). *[Бәдигыльҗамал:] Ибраһим кайтты исә, шуның белән чукыр-чукыр чукырдашалар.* Г.Камал

**ЧУКЫ́Р-ЧУКЫР КИЛҮ** *ф.* 1) Чукыр-чукыр килгән тавышлар чыгару. *Кошлар чукыр-чукыр килә*

2) *күч.* Йомшак кына, тату гына сөйләшү, чүкердәшү. *Килеште алар, чукыр-чукыр киләләр.* С.Шәкүров

**ЧУЛА** *с. сир. иск.* Буй-буй. *Чула тукыма*

**ЧУЛАК** *с.* **1.** 1) Бер кулы булмаган яки имгәнгән. *Сөйләмә инде, алма төсле кызыны бер чулак муллага бирмәсә ярамый идемени?* Г.Исхакый. *Чулак һәм гәүдәгә кечкенә булса да, ир кеше ич әле ул, немецлар килеп кера калса, ирек бирмәс...* В.Нуруллин

2) *сөйл.* Кыска. *Кызыл төймәле әдрәс бишмәтен һәм чулак җиңле бикасап кәзәкиен салып, туны өстенә куйды.* М.Галәү

**2.** *и. мәгъ.* Бер кулы булмаган яки имгәнгән кеше. *Хәерчеләрнең икенче нәүгысе – аксак, сукыр вә чулаклар килә башлады.* Г.Ибраһимов. *Байтак юл үттең, меңәрләгән кешеләрне күрдең. Арада чулаклары күп очрадымы соң?* В.Имамов

**ЧУЛАКЛАНУ** *ф.* Чулакка әйләнү, бер кул имгәнү. *Кирәк бит чулакланырга, узган ел җәй, кечкенә калибрлы мылтык белән тайгага чыккач, аюга очрый бу.* Ә.Маликов

**Чулакланып калу** Билгеле бер вакыйгадан соң чулаклану. *Мирвәли тегермәндә сул кулын имгәтеп, чулакланып калган иде.* А.Гыйләҗев

**ЧУЛАКЛЫК** *и.* Чулак булу хәле. *Чулаклыгы, ямьсезлеге өстенә Каракүз бераз гына аңгырарак та иде.* Н.Фәттах

**ЧУЛА́У** *ф. диал.* Тавышлану, чыр-чу килү. *Мин сәхрәдә җирләнгән мәет күрдем, Аны тоеп чулый чүлдә капланнар.* Ә.Синугыл

**ЧУЛАШ** *и. иск. диал.* Тавышлану, чыр-чу килгән тавыш. *Тышта егетләрнең чулаш, көлешләре ишетелә.* М.Фәйзи

**ЧУЛЛЫК** *и. зоол.* Чуллыкчалар семьялыгыннан озын томшыклы, чуар аркалы саз кошы; *русчасы:* **бекас**. *Чыпчык, чәүкә, күгәрчен, карлыгач, карга, кәккүк, керәшә, сыерчык, акчарлак, карчыга, лачын, сандугач, челән, чөмгә, чумгалак, чүрәкәй, каз, үрдәк, тавык, чәберчек, чукыр, чуллык, --- – болар барысы да гадәти кош исемнәре.* А.Тимергалин

**ЧУЛЛЫ́К БАЛЫК** *и. күпл. зоол.* Чуллык балыклар семьялыгыннан танавы көпшәдәй озынаеп киткән, сырты кызгылт, ян-яклары, корсагы көмешсу төстәге балык

**ЧУЛЛЫ́К БАЛЫКЛАР** *и. зоол.* Чәнечкеле балыксыманнар отрядыннан озын танаулы балыклар семьялыгы

**ЧУЛЛЫ́КЧАЛАР** *и. күпл. зоол.* Арыш чыпчыклары отрядыннан озынрак аяклы, озын томшыклы кошлар семьялыгы

**ЧУЛПАН** *и.* Кояш системасында Меркурий белән Җир арасындагы планета; *русчасы:* **Венера**. *Таң алдыннан Чулпан күренә.* А.Тимергалин

**ЧУЛПА́Н ЙОЛДЫЗЫ** *и. к.* **Чулпан**. *Чулпан йолдызы ялт итеп балкып тора иде.* Гали Рәхим. *Чулпан йолдыз калыкканчы байтак эшләр бар!* А.Гыйләҗев

**ЧУЛПЫ** I *и. этн.* Хатын-кызларның чәч толымына кушып үрелә торган, бауга яки тасмага таккан тәңкәләрдән гыйбарәт бизәнү әйбере. *Моның яулыгы да, артындагы чулпысы да бер төрле зиннәт бирәләр иде.* Г.Ибраһимов. *Әлфия чулпыларын чыңлатып йөгереп чыгып китте.* Г.Әпсәләмов

**ЧУЛПЫ** II *и. иск.* Тал чыбыгыннан, камыштан челтәрләп үреп ясалган чүмеч. *Иләк чулпыга: «Синең тишегең тугыз», – дигән.* Әйтем

**ЧУЛТ** *иярт.* **1.** Берәр артык зур булмаган авыр нәрсә суга төшкәндә, балык сикереп алганда, үбеп алганда һ.б.ш. очракларда барлыкка килгән тавышны белдерә. *Яр буенда черки сагалап утырган ахмак бакалар, аннан куркып, чулт та чулт суга чума башлыйлар.* А.Гыйләҗев

**2.** *хәб. функ.* Берәр нәрсә суга яисә савыт эченә килеп төшү. *Итен кимерәмкимерәм дә, сөяген чулт – кәстрүлгә.* З.Фәтхетдинов. *Абзагыз тегеесасы чанга чулт, бөтен өстәге киемнәр белән...* З.Зәйнуллин

**ЧУ́ЛТ ИТҮ** *ф.* Чулт сыман тавыш чыгу. *Еракта чулт иткән тавыш ишетелде, һәм суга баткан таш урынында берсе эченнән берсе калкып чыгып һаман зурая барган түгәрәкләр генә калды.* Г.Әпсәләмов. *Шул мәлдә суга чулт итеп бака сикерде.* Ф.Җамалетдинова

**ЧУЛТЛА́У** *ф. сөйл.* Берәр нәрсә суга төшкәндә, балык сикергәндә һ.б.ш. очракларда чулт сыман тавыш чыгару. *Бу туфрак шунда чултлап суга төште.* М.Гафури

**ЧУ́ЛТ-ЧУЛТ** *иярт.* Артык зур булмаган авыр нәрсәләр суга төшеп киткәндә, эре тамчы тамып-тамып алганда, балык сикереп-сикереп алганда, үбешкәндә һ.б.ш. очракларда барлыкка килгән тавышны белдерә. *Әллә шунда малайлар чулт-чулт сикереп төшеп йөзәләр идеме, әллә ана каз, канатларын суга тиереп, яртылай очып, яртылай йөзеп читләрне куганда аларны югалта идеме?* Г.Исхакый. *Айрат белән чулт-чулт үбешәсез бит.* Ф.Яруллин. *Ярдагы таллыкта әллә ниткән кошлар үзәкне өзә, чулт-чулт балыклар чума, черкиләр безелди.* К.Кара

**ЧУ́ЛТ-ЧУЛТ ИТҮ** *ф.* Чулт-чулт сыман тавыш чыгу. *Ә тирә-якта, чулт-чулт итеп, пулялар су чәчрәтәләр...* Г.Әпсәләмов

**ЧУ́ЛТ-ЧУЛТ КИЛҮ** *ф.* **чулт-чулт итү**. *Су өстендә кояш шәүләләре уйный, анда-санда, чулт та чулт килеп, балыклар сикерешә.* Г.Бәширов. *Түгәрәк күлне урталай бүлеп, озын ак тасмадай сузылган ай нурлары җем-җем ялтырый, көмеш тәңкәле балыклар чулт-чулт килеп сикерешеп уйный.* И.Диндаров

**ЧУЛЫГУ** *ф. диал.* Ябыгу, ябыгып кечерәеп калу. *Күгәрченнәр бөтенләй чулыгып, чыпчык хәтле генә булып калдылар.* В.Нуруллин

**ЧУЛЫК** *и. иск.* Баланың баласының баласы

**ЧУМ** I *и. иск.* Орлык саклау өчен зур чүлмәк

**ЧУМ** II *и. коми этн.* Төньяк халыкларында өсте кабык, киндер, болан тиресе белән ябыла торган конус формасындагы чатыр

**ЧУМА** *и.* 1) Эпидемия китереп чыгара торган үтә йогышлы авыру. *Миндә йогышлы чир... Грипп, бума, чума хастасы!..* А.Гыйләҗев. *Илгә ачлык килмәсен, Ачтан халык үлмәсен, чума чире йөрмәсен!* Г.Дәүләтшин

2) *күч. сөйл.* Дуамал, тиле, шашкан кеше

**ЧУМАК** *и. иск.* 1) Электә Украинада: Кырымга ашлык һәм авыл хуҗалыгы продуктлары алып барып, ә аннан сату өчен тоз, балык һ.б.ш. ташучы крестьян. *[Карт:] Яшьрәк чагымда чумак булып та йөргәләдем.* Г.Бәширов

2) Чит илдән аз-азлап товар алып кайтып сатучы. *Поезд чумаклар (челноклар) белән шыгрым тулы, барысы да товарга бара.* М.Әмирханов

**ЧУМАКЛЫК** *и.* Чумак булып йөрү, йөк ташу белән шөгыльләнү. *Крестьяннар читкә эшкә киткәннәр, бигрәк тә чумаклык – йөк ташучылык эшенә күп китә торган булганнар.* СССР тарихы

**ЧУМАН** *и.* 1) Чанага куеп тирес, кибәк һ.б.ш. ташу өчен, талчыбыктан үрелгән зур кәрзин. *Ничә чуман бәрәңге генә бушатканбыздыр бүген, корыда эш итик дип азапланган көн, алар, бер әтрәт айгыр күк кызлар, өйдә бурсып яталар!..* А.Гыйләҗев. *Габделхәй абзый кияве бүләк иткән коңгырт әтәчне тавыкларыннан аерып, мунча өйалдында чуман астында өч көн рәттән ач тотты.* Р.Батулла

2) Тарантасның утыру өчен чыбыктан үреп ясалган әрҗәсе. *Ярый ла икенче шешә аракыны, тарантас башын өстәл итеп, чуманга утырып эчте, югыйсә урманда аунап калган булыр иде.* М.Хуҗин

**ЧУМАР** *и.* 1) Кайнап торган шулпага, сөткә төче камырдан өзеп-өзеп салып пешерелә торган кисәкләрдән гыйбарәт ризык. *[Бәдри:] Балалар да ач, кичә дә аз гына чумар уып ашаткан идем.* М.Гафури. *Чумар быкыр-быкыр кайнап утырсын иде, тәмле исләр чыгарып...* А.Гыйләҗев

2) Шундый камыр кисәкләре салып пешерелгән аш. *Ике көн рәттән токмач та кашык чумары!* А.Гыйләҗев. – *Бүген төшке ашка чумар пешереп ашаткannar, – дип елмайды Илсөяр.* А.Фәләх

◊ **Чумар белән сыйлау** Килгән кешене кунак итмәү, сыйламау

**ЧУМАРА** *и. гади с.* 1) Алдаулы яки законлы булмаган юл белән алынган табыш; җиңел юл белән килгән файда. *Сәнгать өлкәсендә, театрда чумара да, коррупция дә, малтабарлык та була алмый.* Р.Вәлиев. *Борчылма, әнә Сәлимә белән генә танышып ал, сиңа да чумара күрәргә туры килер.* Д.Салихов

2) Өстәмә эш. *Өстәвенә, урманга чумарага баргач, авыр агач күтәреп, эчне авырттырдым.* Н.Хәсәнов

3) Ришвәт. *Безнең илдә гадәт шундый: Эшең барса мактыйлар. Чумара да бирә белсәң... Бәйләнмиләр, мактыйлар.* И.Гыйләҗев

**ЧУМАРАЛЫ** *с. сөйл.* Җиңел табыш бирә торган; табышлы; төшемле. *Син дә чумаралы эшкә кер.* Ә.Галиев

**ЧУМАРАЧЫ** *и. сөйл.* Чумара эшләүче. *[Нәҗибә:] Өстерәлчек. Чумарачы.* А.Гыйләҗев

**ЧУМАРКҮЗ** *и. гади с.* Зур күзле, акай күзле кеше. *[Хәлим:] Хәлфә --- чумаркүз, капкорсак, дип ачулана.* И.Гази

**ЧУМАРЛЫК** *с.* **1.** Чумар пешерүгә тотыла торган, чумарга китә торган. *Чумарлык он*

**2.** *и. мәгъ.* Чумар пешерү өчен кирәк булган нәрсәләр. *Чумарлык әзерләп кую*

**ЧУМА ТОЗЛАГЫ** *и. бот.* Алабуталачалар семьялыгыннан вак кына яфраклы һәм чәчәкле берьеллык үсемлек; *русчасы:* **поташник**

**ЧУМГАЛАК** *и. зоол.* Үрдәкчәләр семьялыгыннан зур башлы, кыска муенлы, азыкны суга чумып таба торган үрдәк; *русчасы*: **нырок**. *Колакларым, очып барган чумгалаклар көтүе чыгарган кебек, гүләү белән тулды, ә юл буендагы агачлар тоташ соры чаршау булып кушылды.* Казан утлары. *Соңгы елларда кряква дигән кыргый үрдәк калгаласа, хәзер чумгалак дигәне һәм тагын башка бер төре дә бездә кышлый башлады.* Шәһри Казан

**ЧУМГЫЛ** *и. сөйл. к.* **чоңгыл**. *--- ул төссез, иссез, хәрәкәтсез шомлы чумгылда бер башы торып калды.* А.Гыйләҗев

**ЧУМГЫЛЛАНУ** *ф. сөйл.* Тирән булып күренү

**Чумгылланып тору** Һәрвакыт чумгыллану, әле, хәзер чумгыллану. *Бәке Чаган бозы өстендәге күкселләнеп яткан кар уртасында караеп, чумгылланып тора.* Ә.Фәйзи

**ЧУМДЫРУ** *ф.* 1) Нинди дә булса сыеклыкка яки сибелүчән, йомшак нәрсәгә батыру. *Искәндәр аның кулын артка каерып китерде дә башын карга чумдырды.* Р.Вәлиев. *Егет ачуярсуыннан кайнар казанга чумдырган кысла сыман кызарынып чыкты.* В.Имамов. *Үзе бер хәл, ул балалар бакчасындагы сабыйларны да һәр иртәне салкын суга чумдырганнарын белә, кызын кызгана иде.* М.Маликова

2) Баштанаяк, тулысынча күмү; батыру; буяу. *Сүбүдәй аны салкын тиргә чумдырырлык котккы уйлап тапты.* В.Имамов. *Ә без һаман, туган җиребезне мазутка чумдырып, нефть чыгарабыз, бабаларыбыз күмелгән каберләрне күчереп, КамАЗлар, ТатАЭСлар корабыз.* Р.Вәлиев. *Шул арада өченче күз табигатьне сарылыгына чумдырды.* А.Нәҗми

3) *сөйл.* Төшереп җибәрү, салу, эчкәрәк, аскарак тыгу. *Әнил телефонын сумкасына чумдырды да Кәримәгә карап күз кысып куйды.* З.Хөснияр. *Икешәр капчык арыш тутырдык та арба төбенә чумдырдык, өстенә салам салдык.* Р.Газиз. *Ике коймакны бөтереп авызга чумдырдым.* Л.Лерон

4) Кемгә дә булса нәрсәнедер бик күп итеп, мул итеп бирү, тәэмин итү. *--- әгәр ул минем хатыным булса, мин аны башыннан аягына кадәр алтынкөмешкә чумдырыр идем, гомер буена киендереп, ясандырып, бик рәхәт итеп тотар идем.* Г.Камал

5) Берәр хәлгә дучар итү. *Бу көй шулкадәр тәэсирле иде, нинди җиңел уйлы җилбәзәкләрне дә бик тирән фикерләргә чумдыра иде.* Г.Исхакый. *Атларыбызны тышаулап, йөгәннәрен салдырып, шул иркенлеккә чумдырабыз.* К.Миңлебаев. *Син, Аяз, Мәһдине тоташ мәдхиягә чумдырып аздырма.* Т.Галиуллин

**Чумдыра бару** Булган берсен чумдыру. *Туфан абый бүтәннәрнең игътибарына күчә, аларның да күңелләрен аптырашка чумдыра бара.* Ф.Яхин

**Чумдыра башлау** Чумдырырга тотыну. *Бераздан ул инде кулларын терсәкләренә кадәр, аннан соң иңбашына кадәр чумдыра башлады.* Ф.Абдуллин

**Чумдырып алу** Тиз генә чумдыру. *Ул сары буяуга башын чумдырып алган пумала очы сыман сап-сары иде.* А.Хәлим. *Берсенең шулай дип әйтүе булды, икенчесе, кулына күз ияргәнче, Гөләшне яннарындагы сулы кисмәккә чумдырып та алды...* Г.Гыйльманов

**Чумдырып бетерү** Баштанаяк чумдыру. *Кар белән батырып, чумдырып бетерде, чукынчык!* Ф.Яхин

**ЧУМИ́ЗА** *и. кыт.* Кыяклылар семьялыгыннан бөртекләреннән он, ярма әзерләнә һәм үзе терлек азыгы итеп кулланыла торган үсемлек; кытай тарысы. *Яз көне тагын безгә чумиза чәчәргә куштылар.* Т.Гыйззәт. *Ә мин хәзер бөрткән чумизаны Коймактан да тәмле дип беләм.* Ф.Кәрим

**ЧУМУ** *ф.* 1) Баштан кадәр суга күмелү. *Чокыр тулгач, шул күлдә тәннәребез күгәргәнче коенабыз, чумабыз, кушып уйныйбыз.* А.Хәлим. *Маска киеп, авызга көпшә кабып чумарга өйрәнсәң шәп инде, әлбәттә.* А.Тимергалин

2) Әйберләр сыеклыкка, йомшак әйбергә бөтенләй кереп күмелү. *Шулай да причал белән орынышкан мизгелдә бөтен пароход тетрәнеп, шыгырдап, җан ияседәй ыңгырашып куя, һәм аның бер дә кирәксезгә чыгырдан ычкынган авыр якоре суга чума.* А.Тимергалин

3) Бату. *Ә мин, теземнән туфракка чумып, әбиләр бакчасында бәрәңге өям.* А.Гыйләҗев. *Быел кар тирән, бот төбеннән карга чумып, кармаланып, хәтта йөзеп барырга туры килә.* Г.Гыйльманов

4) Аска, төпкә төшеп китү. *Без, шунда ук кире чокырга чумып, бар көчебезгә килгән якка йөгермәбезме...* М.Яһудин

5) Элеккегедән эчкәрәк батып китү, тирәнрәк урнашу. *Чалкан яткан Сабираттәйнең ияге очлайган, күзләре төпкә чумган, чырае танымаслык булып үзгәргән иде.* А.Гыйләҗев

6) Берәр йомшак нәрсәгә күмелү; баштанаяк каплану, сеңү. *Шуның түрендә матур, бай мехларга чумып, графинялар кебек башын арткарак салып утырган...* Г.Ибраһимов. *Элеккечә хәрәкәтсез булып, авылга кайткач балкыбрак киткән, әмма моңсулыгын югалтмаган күз алмаларын як-якка тәгәрәтеп, әнкәсенең йомшак түшәгенә чумып ята бирде.* Г.Гыйльманов. *Мин үзем яттым чананың өстенә, тунга чумып ---.* Б.Мирзанов

7) *сөйл.* Биектән егылып төшү. *Таңга кадәр шкаф артында басып торган да, хуҗа иртә белән тамбурга тәмәке тартырга чыккач, турая алмыйча, куркуыннан дүртенче кат балконыннан чумып, бот сөяген сындырган.* З.Мәхмүди

8) *сөйл.* Берәр кая тиз генә кереп качу, кереп югалу. *--- көнбагышлар эченә кереп чумам да ул узып китмичә аннан чыкмыйм.* А.Вергазов. *Алевтина Петровна шундук аш-су бүлмәсенә чумды ---.* А.Хәлим

9) *күч.* Берәр уй-фикергә бирелү, уйга бату. *Әллә нинди берсеннән-берсе матур фикерләргә чума идем.* Г.Исхакый. *Уйларына чумып, тау итәгендәге алачыкка килеп җитүен дә искәрмәгән икән.* А.Әхмәтгалиева // Берәр хискә талу. *Барысы, үз хәсрәтенә чумып, аның җырын тыңлый.* Г.Әпсәләмов. *Бөтен*

*авыл мәет чыккан йорт кебек кайгыга чумды.* Г.Бәширов

10) *күч.* Бик нык бирелеп эшләү, берәр нәрсә белән мавыгып шөгыльләнү. *Дәртләнеп эшкә чумасың, ул гына да әз, тагын ныграк чумарга, үзеңне җиңәргә кирәк.* А.Алиш. *Баш-аягы белән компьютерга кереп чумган иде ул.* А.Гыймадиев // Бик күп эшләү. *Әйе, син хәзер миннән башка эшкә чумып яшим димәкче буласың.* Г.Каюмов. *Икесе дә, китапларга чумып, үткән теманы кабатларга тырышсалар да, башларына берни кермәде.* И.Диндаров

11) *күч.* Нәрсә белән дә булса каплап, чолгап алыну, күмелү, өртелү. *Бакча башыннан шау чәчәккә чумган юкәлек башлана.* Р. Мөхәммәдиев. *Тау артына күчәргә җыенган кояш нурларында аның сырты, кызгылт төскә чумып, елык-елык килә.* А.Хәсәнов

12) *күч.* Шатлыкка, бәхеткә һ.б.ш. ия булу. *Һәрнәрсә аның чиге булмаган матурлыгына, моңына баш ия, барлык җирен аның гүзәллеге чолгый да, йомшак кына, яшерен генә, тын гына булган шатлыкка, бәхеткә чума.* Г.Ибраһимов. *Иркәләшеп, назга чумып яшик, Балкыганда гомер көзебез.* В.Галиев

13) *күч.* Бик зур байлыкка, муллыкка ия булу. *Ә теге туймас күз хатыны кыйммәтле туннар ала, алтынга чума, яшь бер спортсмен белән типтерә башлый.* Р.Батулла. *Малга, алтынга, татлы ризыкка күнеккән, муллыкка чумып яшәгән ыру кайчан да булса бер җиңелә ул.* З.Хәким

14) *күч.* Матди яктан авыр хәлгә төшү. *Тегеләй итте, болай әйләндерде, саклык кассасында хатыныннан яшереп тоткан акчасын (күпме алып кайтсаң да, юкка-барга туздырып бетерә) алды, бурычка чумды.* Т.Галиуллин. *Шул бер баруыңда баеп яисә тәмам бөлеп, кабалага чумып кайтуың бар.* А.Хәсәнов

**Чума бару** Торган саен чуму. *Икенче минутта ул, онытылып, каядыр йомшак мамык эченә чума барган кебек булды.* Х.Камалов. *--- гөнаһка көннән көн тирәнрәк суырыла, чума баруын да аңлый ---.* В.Имамов

**Чума башлау** Чумарга тотыну. *Яр буенда черки сагалап утырган ахмак бакалар, аннан куркып, чулт та чулт суга чума башлыйлар.* А.Гыйләҗев. *Соңгы арада шулай бик еш хыялга чума башлады әле ул.* Р.Вәлиев

**Чума бирү** Бераз чуму. – *Фу, Вәли, син икәнсең, танымый торам!.. – дип, тиз атлап, өстәл буендагы зур тирән креслога чума биреп утырды.* Г.Ибраһимов

**Чума төшү** Бераз генә чуму, тагын да чуму. *Госманның ярым караңгы кабинетында, тирән креслога чума төшеп, үзенең зур трубкасын кабып, Булатов утыра.* Г.Ибраһимов. *Укытучысы килүгә куанса да, каушавыннан, оялуыннан Рахман шундук юрган астына чума төште.* Н.Әхмәдиев

**Чумып алу** Тиз генә чуму. – *Әйдә, чумып кына алыйк, – диде кызларның берсе.* Г.Гомәр. *Абынып, карга чумып та алды.* М.Садыйков

**Чумып бару** Акрынлап чуму. *Ләззәтле уйларга чумып барган бер мәлдә ул нининдидер безелдәгән тавыш ишетте.* К.Тәхау. *Караңгылыкка чумып барган Берлинның таш урамнарыннан юеш кара плащ кигән – һаман яңгыр ява иде – бер хәрби кеше бара.* Г.Әпсәләмов

**Чумып бетү** Бик нык чуму. *Тубыктан да, тездән дә суга чумып беттек.* А.Хәсәнов

**Чумып йөрү** Озак вакытлар чумган хәлдә булу. *Җәйге каникулда эшкә чумып йөрү күңеленә бик үк ятмаса да, Мортазин аны-моны сиздермәде.* В.Имамов

**Чумып калу** Берәр вакыйгадан соң чумган хәлдә булу. *Бачман Сүбүдәйне җиңеп озатса да, Болгар иле, мәет озаткан йорт шикелле, шомга чумып калды.* В.Имамов

**Чумып китү** Кинәт чуму. *Утырыйм дисәң, алар [креслолар] эченә чумып китәсең.* А.Хәсәнов. *Әнә бит стенадагы тишекләр урынында якты тәрәзәләр, сәкеләре дә йомшак, утырсаң – чумып китәсең, бүкәннәре дә, бәрән кебек, дүрт аяклы, менә-менә сикергәләп йөгереп китәр төсле...* Г.Гыйльманов

**Чумып кую** Көтмәгәндә чуму. *Тик ара-тирә кармак очына дүрт канатлы энә карагы килеп куна, яки су уртасында берәр балык сыртын елтыратып чумып куя.* Ә.Еники. – *Башкаларга кое казыма, үзең чумып куймагаең, – дип әйтергә генә.* А.Хәсәнов

**Чумып тору** Әле, хәзер чумган булу. *Зифа бик озак вакыт буена уйга чумып торды.* В.Имамов. *Торасың син чумып кайгыга, Сөялгәнсең ялгыз каенга.* В.Хәйдәрова

**ЧУМЫЛДЫРУ** I *ф. к.* **чукындыру** (*2 мәгъ.*). *Бәчкәсе белән киңәшминитми, дүрт баланың икесен әнә шул попка алып барган да чумылдырып кайткан.* Г.Рәхим

**ЧУМЫЛДЫРУ** II *и.* Христианнарда рәсми рәвештә христиан диненә кабул итү йоласы. *Пикыла белән Бәчкә балаларны чумылдыру мәсьәләсендә дә килешә алмадылар.* Г.Рәхим

**ЧУМЫРГЫЧ** *и.* Сыеклыкны яки сибелүчән әйберләрне чумырып алу өчен хезмәт итә торган савыт, соскыч

**ЧУМЫРУ** *ф.* 1) Сыеклык эченә батырып алу; чумдыру. *Ишкәк башларын суга чумырып бер киерелгәч, ялыккан, тик торып арыган беләк мускуллары, бөтен тәне буенча күңелле бер рәхәтлек йөгергәч, юк-бар нәрсә онытылып, артта – яр читендә торып калды.* Н.Фәттах

2) *сөйл.* Су яки башка сыеклыкка ташлап, салып батыру. *[Егет] әрҗә эченә авыр бер таш салып, аны су төбенә чумырган, озын бауның бер очын үзендә калдырган.* Г.Гали

3) Сыек яки сибелүчән әйберне күп итеп сосып алу. *Казан янына килүчеләргә, олы чүмеч белән чумырып, итле аш салып бирәләр.* Ф.Яруллин. *Су бик сай иде, чиләк белән чумырып булмый.* Х.Камалов. *Чиләктән чынаяк белән су чумырды.* М.Маликова

4) *күч.* Нәрсәне дә булса бик күп итеп алу; күпләп үзләштерү. *Складтан мул гына тегесен-монысын чумырган идек, капчык авызын киң чиштем.* Х.Камалов

5) *күч.* Күп итеп, кирәгеннән артыгын куллану. *Кайсыдыр бер елны Салих абый ухага тоз чумырган икән – ашамаслык булып, яңадан пешергәннәр икән.* З.Зәйнуллин

6) *күч.* Нәрсәне дә булса мул бирү; нәрсәгә дә булса тиендерү. *Әмма табигать гайрәт биргәнгә, акылны артык чумырмаган, акыллыга – көч-куәтне.* Ф.Яруллин. *Ул, язарына азыкны хәзерге чынбарлыктан чумырып алса да, төп игътибарын лиризм, моң ярдәмендә кеше кичерешләрен ачуга юнәлтә.* Т.Галиуллин

**Чумыра башлау** Чумырырга тотыну. *[Мамлиев:] Минем киткәнне генә көтеп торган кебек, кайсы кайдан чумыра да башлаганнар.* Х.Сарьян

**Чумырып калу** Чумырырга өлгерү. *[Бәдри:] Урыны килгәндә чумырыбрак калырга кирәк. Бер эләктерсәң, шушы туй аркасында эләктереп каласың аны.* М.Фәйзи. *Ә бераздан инде, кулга үзе килеп кергән байлыкны кем күбрәк чумырып калганлыгын белер өчен,*

*бакчачылар бер-берләренә визит ясый башладылар.* Ф.Яруллин

**ЧУМЫШЛЫ** *и.* Суда берсе икенчесеннән тирәнрәк чумарга тырышудан гыйбарәт балалар уены. *Анда без аккошлар белән танышабыз, бергәләп чумышлы уйныйбыз, качышлы уйныйбыз.* Ә.Баян

**ЧУҢКАЙТУ** *ф. диал.* Кыйшайту. *[Илтуганов:] Авызыңны чуңкайттырып, урам чатында басып, тәмәке төтене белән яшь үпкәләреңне агуламакчы буласыңмы?* Д.Аппакова

**ЧУП** *иярт.* 1) Үпкәндә барлыкка килгән тавышны белдерә. *[Закир:] Бервакыт шулай бер компаниядә ике кыз чуп үбештеләр.* Ф.Әмирхан

2) *сир.* Тамчы сулырак урынга тамганда, суга сикергәндә һ.б.ш. очракларда барлыкка килгән тавышны белдерә

**ЧУП-** *кис.* [ч] авазына башлана торган кайбер сыйфатларның артыклык дәрәҗәсен ясый торган алкисәкчә. *Башка вакытта боз өсте чуп-чуар була торган иде, бүген беркем дә юк.* Л.Ихсанова. *Ямь-яшел яфраклар һәм чуп-чуар болыннар өстенә нindидер аклык төшкән.* Ф.Яруллин

**ЧУПАЙ** *и. диал.* **1.** 1) Байгыш

2) Бармагын суыручы яшь бала. *Чупай барыбер бармак имүдән бизмәде.* Р.Батулла

**2.** *с. мәгъ.* Аз сүзле, тыныч

**ЧУПАН** *и. иск.* Сарык көтүчесе; чабан. *Аннан соң күзен тотып: «Әй, чупан, атымны китер, күземә тузан керде», – дип, күзен тотып, атына атланып китте.* К.Насыйри

**ЧУПА́Н ТАЯГЫ** *и. бот.* Яранчалар семьялыгыннан чук тамырлы биш таҗлы ал чәчәкле үлән үсемлек; көтүче энәсе; *русчасы:* **аистник**

**ЧУПА-ЧУПС** *и. исп.* Таякчыкка утыртылган шар формасындагы суыра торган конфет. *Кассага барыр идем дә Күп акча алыр идем, Кырык бер чупа-чупсны Кесәгә салыр идем ---.* И.Юзеев

**ЧУ́П ИТҮ** *ф.* 1) Чуп сыман тавыш чыгару. *Тамчылар, чуп итеп, нигез буендагы челтәр карга тамып төштеләр.* Р.Төхфәтуллин. *Сикергәндә куллaрын кушырып, аякларын бергә куеп, күл йөзен җыерчыкландырмый гына, чуп итеп төшеп китте ул төнкә.* Г.Якупова

2) Үбеп алу; пәп итү

**ЧУ́П КИЛҮ** *ф.* **чуп итү** (*1 мәгъ*). *Су өстендә кемнеңдер көймәсе чайкала, чуп та чуп килеп, вак дулкыннар шаярыша, назлы җил битләрне иркәли.* М.Әмирханов

**ЧУПТАР** *и.* Тукымага сугып төшерелгән бизәк. *Аса, чуптар дип йөртелә торган тукыма бизәкләр, туку техникасына буйсындырылганлыктан, киртләч-киртләч геометрик фигура рәвешен алганнар.* Казан утлары

**ЧУПТАРЛА́У** *ф.* Тукыганда бизәк төшереп сугу, бизәкләп сугу. *Чуптарлап туку бик үк киң таралыш алмаган булса да, җирле халыкта бу техника буенча эшләнгән әйберләр дә очрата алдык.* Милли-мәдәни мирасыбыз: Нижгар татарлары

**ЧУПТАРЛЫ** *с.* Чуптарлап сугылган, тукылган. *Юылган башны чуптарлы сөлге белән бик озак сөрткәч, Люда креслоны яңадан көзгегә таба бордыртты.* М.Мәһдиев

**ЧУПЧЫЛДАТУ** *ф. сир. к.* **чупылдату**. *Барып, чупчылдатып авызын, Сүзен чын-хаклатыр былбыл.* Н.Думави

**ЧУПЫЛДАТУ** *ф.* 1) Үпкәндә, бала имгәндә һ.б.ш. очракларда яңгыравык тавыш барлыкка китерү. *Бит уртасыннан чупылдатып үбеп аласым килә.* Г.Әдһәмова. *Сабый, авызындагы имезлекне чупылдатып, тәмләп йоклап ята.* А.Әхмәтгалиева

2) Ишкәкне суга бәреп алганда һ.б.ш. очракларда яңгыравык тавыш барлыкка китерү. *Суны чупылдатмыйча, чәчрәтмичә генә ишеп, ишкәкне кабыргасы белән суга төшерү һәм судан чыгару осталыгына өйрәнергә кирәк икән.* А.Тимергалин. *Күпме тылсым сыйган балыкларның Суны чупылдаткан тавышына.* Р.Низамиев

**Чупылдатып алу** Бераз чупылдату. *Гали абзый, бармагын баланың нәни аяк астына куеп, иренен чупылдатып алды.* Г.Әпсәләмов. *Ул иренен чупылдатып алды.* Р.Галиуллин

**Чупылдатып кую** Бер тапкыр чупылдату. *Бала авызын чупылдатып куйды.* Р.Зәйдулла

**ЧУПЫЛДА́У** *ф.* Берәр тәэсир нәтиҗәсендә су чайкалып, дулкынланып, үзенә бертөрле тавыш барлыкка китерү. *Сазлыкларга кергәндә, аяк астында җылы су чупылдый.* Г.Әпсәләмов. *Чирәм араларында вак дулкыннар ясап чупылдаган су аның тәпиләрен кызыктырып кытыклады.* А.Гыйләҗев. *Аннаның кашыгы чупылдап шулпага төште.* М.Маликова

**Чупылдап кую** Бер тапкыр чупылдау. *Аның кесәсендәге шешә чупылдап куйды.* Р.Вәлиев

**Чупылдап тору** Әледән-әле чупылдау; әле, хәзер чупылдау

**Чупылдап утыру** *сөйл. к.* **чупылдап тору**. *Элек тулы суына киерелеп, искән җилгә чупылдап утырган яр буйларында тузан өермәсе йөри.* М.Мәһдиев

**Чупылдый башлау** Чупылдарга тотыну. *Ләкин, көтмәгәндә, яр ягыннан су чупылдый башлады, камыш сабаклары кыштырдады.* В.Имамов. *Салкын кышлар үтеп, табигатьтә яз галәмәтләре сизелеп, беренче тамчылар чупылдый башлаган көннәрнең берсендә, Вәлиулланың әтисе Кәбир карт янына кордашы Галиәкбәр абзый килеп керә.* Р.Низами

**ЧУПЫРДА́У** *ф.* 1) Су акканда, суда берәр нәрсә хәрәкәт иткәндә, сулы җир өстеннән барганда һ.б.ш. очракларда яңгыравык тавыш барлыкка китерү. *Аяк астында су чупырдады, алдан гайрәт белән юл күрсәтеп Мөнир бара, аңа Халисәсе тагылган.* А.Гыйләҗев

2) Артык озак су керү, су белән маташу. *Суда сәгатьләр буена үрдәк булып чупырдый бу, әй!* А.Хәсәнов

3) Йөзә белмичә йөзәргә тырышу. *Ахияр абый, мин бит йөзә белмим, яр кырыенда гына чупырдыйм инде шунда.* Г.Галиева

**Чупырдап алу** *к.* **чупырдап кую**. *Аннары су бер чупырдап ала, бераздан чәчләрне йоткан түгәрәк дулкыннар да тына, тынычлана...* А.Тимергалин

**Чупырдап кую** Бер тапкыр чупырдау. --- *буадагы маймычның чупырдап куюы да аңа бик күп нәрсә аңлата иде.* Р.Вәлиев. --- *шул сихри тынлыкны бозарга курыккандай, чикерткәләр дә сайравыннан туктап калган: бары тик ара-тирә елгада зур балыклар йокы аралаш чупырдап куя* ---. Р.Мирхәйдәров

**Чупырдый башлау** Чупырдарга тотыну. *Бераздан аяк асты чупырдый башлады – су!* Р.Юныс

**ЧУПЫ́Р-ЧУПЫР** *иярт.* Су акканда, суда берәр нәрсә хәрәкәт иткәндә, сулы җир өстеннән барганда һ.б.ш. очракларда ишетелгән кабатлаулы яңгыравык тавышны белдерә. *Иртән үк йөгерәбез, Туйганчы су керәбез: Чупыр-чупыр чумабыз Култыктагы суга без. Кайнар комга чыгабыз* ---. М.Шабаев. *Саз күлендә чупыр-чупыр кыр үрдәкләре коена, ахрысы.* Н.Гыйматдинова

**ЧУПЫ́Р-ЧУПЫР ИТҮ** *ф.* Чупыр-чупыр сыман тавыш чыгару. *Ләкин караса – тагын бәла: дәү бер эт, чупыр-чупыр итеп, аның катыгын эчеп тора, имеш.* М.Галәү

**ЧУПЫ́Р-ЧУПЫР КИЛҮ** *ф. к.* **чупыр-чупыр итү**. *Ара-тирә вак балык артыннан куучы чуртаннар гына, чупыр-чупыр килеп, суны болгатып алалар.* М.Әмирханов

**ЧУР** I *ы. сөйл.* Нинди дә булса килешүне, шартны үтәргә үтенүне, искәртеп куюны белдерә. *Чур, отсаң, икебезгә уртак!* Н.Әхмәдиев. *Чур, карама, син мине күрергә тиеш түгел; бүген мин – синең хуҗаң, ә син минем колым булырсың.* Г.Гыйльманов

**ЧУР** II *и. иск.* Славяннарда ерак баба, ыруг башлыгы. *Славяннар үзләренең үлгән ыруг башлыкларын – бабаларын хөрмәтләп искә ала торган булганнар. Андый баба чур дип аталган.* СССР тарихы

**ЧУР** III *иярт.* Бакалар кычкырган тавышны белдерә. *Су буеннан бакаларның чур-р-р-чу-урр җыр сузулары ишетелә ---.* Ф.Садриев

**ЧУРА** *и.* 1) *иск.* Әсирлеккә төшеп кол ителгән кеше. *Олугымбикә, китмә коллыкка, мин чураның хәлен беләм, Сафагәрәй хан коткармаган булса, мин коллыкта инде күптән черегән булыр идем, коллар озак яшәми.* М.Хуҗин. *Аннары торды да ишекле-түрле йөренергә кереште, ахыр чурасына кымыз һәм ризык китерергә кушты ---.* М.Хәбибуллин

2) *тар.* Урта гасырларда ханнарның сәяси вассалы, аерым гаскәр башлыгы. *Болгар-йортта чуралар, биләр барысы да кам Аштабарга ышаналар.* А.Гадел

3) XVII–XVIII гасырларда әсирлеккә төшеп крепостной ителгән кеше. *Йомышлы татарлар пленга төшкән кыргыз-кайсак, калмыкларны алып кайтып, үз хуҗалыкларында чура [крепостной] итеп җиргә утырта торган булганнар.* С.Алишев

**ЧУРАГАЙ** *и.* Чуртан баласы, яшь чуртан. *Салих күпердәге чиләген алды да андагы чурагайны Ыкка җибәрде.* Г.Мөхәммәтшин

**ЧУРЛА́У** *ф. сөйл.* 1) Чылтырау. *Авыл урамнарыннан чурлап гөрләвек ага, тополь башларында томшыкларын суыра-суыра сыерчыклар сайрый иде.* М.Мәһдиев. *Аста, әкрен генә чурлап, салкын су ага.* Ф.Абдуллин // Чөмәкләре булган предметларда су кайнап, сызгырып тавышланып алу. *Су краны ватылган, кайнар су, самавыр борыныннан аккандай, көчкә-көчкә чурлап маташа.* Р.Мулланурова

2) Эчәклектә үзенә бертөрле тавыш барлыкка килү; эч кычкыру. *Карыны ачты малайның, эче чурлады.* А.Гыйләҗев

3) Бакалар, чикерткәләр сайрау. *Каберлек тирәсендә куе булып чәчәкле үлән үскән, кич белән анда чикерткәләр чурлый, чәчәкләрдән бал исе тарала...* М.Мәһдиев. *Тирә-якта чикерткәләр ярыша, буада бакалар чурлый.* Р.Батулла

**Чурлап тору** Даими чурлау; әле, хәзер чурлау. *Кыз белән бергә Әлфия дә кызарынды, эче чурлап тора иде, ашыйсы килүе дә онытылды.* Ә.Галиев. *Инде хәзер, көне буе эчең чурлап торганда, каян табарга ул бәрәңгеләрне?* Т.Нурмөхәммәтов

**Чурлый башлау** Чурларга тотыну. *Бу мәхшәр Альфредны да үзенә суырып алды, куркудан аның авызы кипте, эче чурлый башлады.* Ф.Садриев

**ЧУРТ** *и. рус. гади с.* **1.** 1) Начар дип бәяләнгән кем яки нәрсә. *Әллә грипп – чурт инде нindidер...* Г.Акбар

2) Теләсә нәрсә, теләсә кем; әллә кемнәр. *Вообщем, разный чуртлар, мур кыргырлары, Абвер ялчыларының эте-бете.* Г.Әпсәләмов. *Нәҗипнең эче җылынып китте, армиягә алмасыннар гына, тайпылыш түгел, чурт булсын аңа!* А.Гыйләҗев. *Шул авылдан качкан теге Исмай Камилләре, Сажидә Рәшитләре, Хисами малайлары, тагын әллә нинди чуртлар хисабына.* В.Имамов

**2.** *ы. мәгъ.* Тискәре мөнәсәбәтне белдерү өчен кулланыла. *[Тиз генә өстәл янына килә дә полоскательныйны алып кия. Аны ыргытып бәрә дә:] Тфү, чурт!* Г.Камал

◊ **Чурт белгән** *к.* **чурт белсен**. *Чурт белгән монда, буталышып беттегез инде!* А.Гыйләҗев. **Чурт белсен** «Беркем дә белми» мәгънәсендә кулланыла. *Сезнең жен телегезне чурт белсенмени!* Г.Камал. *Нindidер актымы инде шунда, гаризамы – аны чуртым белсен.* В.Имамов. **Чуртка да** Беркемгә дә. *Брачка да, чуртка да күренеп тормадым.* В.Нуруллин. **Чурт кушканмы** «Кем әйткән, нигә эшләдегез» мәгънәсендә кулланыла. *Сезгә чурт кушканмыни!* Г.Камал. **Чурт та** Берни дә. *Әмма аның отряды да, чурты да юк.* А.Хәсәнов. *Мәхәббәт булмаса, матурлык та, чуртым да юк!* Р.Вәлиев. **Чурты да, мурты да** Барысы да. *Син яшь әле, мәхәббәте дә, чурты да, мурты да булыр.* Г.Каюмов

**ЧУРТАН** *и.* Чуртанчалар семьялыгыннан төче суда яшәүче яссы башлы, озынча гәүдәле, үрдәк борынлы ерткыч балык. *Кытыршы тәңкәле алабугаларны, кызылканатларны, ап-ак итле кушбашларны, хәтта беләк буе чуртаннарны да ярга тартып чыгарган чаклар күп булды.* А.Хәсәнов. *Чуртаннарның бер тәүлек җир өстендә ятканнан соң да тере булуларын күргәнем бар, әмма җәеннәр белән очрашкан юк иде әле.* В.Гали

◊ **Чуртан кушуы буенча** Көч куймыйча, үзеннән-үзе. *Бәлкем, суны шуннан гына алырбыз: Газинур соравы, чуртан кушуы буенча, ә?* Г.Әпсәләмов. *Малай йокы сүткән арада, чуртан кушуы буенча, тирмәгә заманча ванна һәм душ белән җиһазланган гигиена бүлмәсе тоташтырып куйганнар иде.* А.Тимергалин

**ЧУРТА́НЧАЛАР** *и күпл. зоол.* Сөләйман балыклар отрядыннан төче сулыкларда яшәүче торпедадай гәүдәле, тимгелле соргылт яшел төстәге балыклар семьялыгы

**ЧУРТКАМЫ** *рәв. сөйл.* Нәрсәгә, нигә, ни өчен; ни кирәккә, ни пычагыма. *– Билет сезгә чурткамыни; Өйгә кайтып киткәндә, – ди, – Ташлыйсыз бит идәнгә, – ди.* Г.Афзал. *Тәвәккәллә, җан көеге булып, Чуртымамы җирдә яшәргә.* З.Мансур

**ЧУ́РТ-МУРТ** *и. гади с.* Әллә нәрсәләр; теләсә нәрсә. *Ул бары тик шаяру гына, монда сихер дә, әллә нинди чурт-муртлар да юк.* А.Гадел

**ЧУ́РТ-ЧУРАМАН** *җый. и. гади с.* Юк-бар нәрсә яки әһәмиятсез, кирәк дип табылмаган, түбән дәрәҗәле кешеләр. *[Халикъ:] – Ни булса да бирәр кәнитил булмый калмый. – Бигрәк тә гает алдыннан. Аның бар фитыры, аның бар садакасы, чурты-чураманы.* Ш.Камал

**ЧУРЫЛДА́У** *ф. диал.* Чырылдау. *Шул чурылдый бит зәңгәр күктә.* Г.Бәширов

**ЧУТ** I *и. рус* **1.** 1) Дүртпочмаклы кыса эчендәге таякчыкларга шуып йөри торган түгәрәк төймәләр тезелгән гади исәп-хисап әсбабы: *русчасы:* **счёты**. *Хисапчы, борыны белән калын гроссбухларга төртелеп, чырт та чырт чутын сала башлады.* А.Гыйләҗев. *Беренче колхоз хисапчысының чуты да, хәтта калькуляторлар кайткач кирәк-*

*сезгә чыккан «Феликс» машинкасы да аңарда.* А.Тимергалин

2) *сөйл.* Исәп, сан. *Юл фаҗигаларының чутын алып бетерешле түгел бит.* А.Хәсәнов

3) Берәр уртак сыйфаты белән бердәй буларак кабул ителә торган төркем. *Коңгырт кара күзле, энҗе шикелле ап-ак, тип-тигез тешле, итләчрәк кенә алсу иренле, куе кара кашлы, елмайган чагында ничектер эчтән балкып китә торган мөлаем йөзле ул кызны ничек итеп ямьсезләр чутына кертмәк кирәк?!* В.Нуруллин. *Ә Казанда анда әллә нинди ханым-туташлар бар, безнең хатыннар чуты гына түгел.* Р.Зәйдулла

4) Рәт, чама, хәл, түземлек. *Крестьянның яшәр чуты калмаган, әллә кая китеп олага идем, шул председательнең күзенә кадалган кылчык булыйм дип кенә монда ятам.* А.Гыйләҗев

**2.** *хәб. функ.* Тиң, бер үк дәрәҗәдәге. *Кем булсам да, сиңа чут түгел.* И.Гази

◊ **Чутка алу** Санлау. *Без кешеләребезнең шушы якка хас табигатен, электән-электән тамыр җибәргән традицияләрен чутка алмый башлаганбыз* А.Вергазов. **Чутка салу** 1) Исәпкә алу, санау. *Шулай булгач, нишләп әле мин дүрт аяклы малны чутка салып торыйм?* В.Имамов; 2) *к.* чутка алу. **Чутка тыгу** *к.* **чутка алу**. *Патша барында безнең крестьяннарны чутка тыкмый йөргән бер кеше хәзер үзгәргән.* Х.Кәрим. **Чуттан төшү** Санга сугылмый башлау. *Билгеле инде, өлкән һәм урта буын да чуттан төшмәгән.* А.Әхмәдуллин. **Чуттан чыгарып ташлау** Кем яки нәрсә белән дә булса санашмый башлау, игътибарсыз калдыру. *Шуңа күрә, бары тик атамадан чыгып кына, тәнкыйди реализм әдәбиятындагы уңайны раслау принцибын чуттан чыгарып ташлау дөрес булмас.* А.Әхмәдуллин. **Чутта булмау** Санланмау; дәрәҗәсе булмау. *Үзегез беләсез, бездә кеше чутта түгел.* А.Хәмзин. **Чут түгел** 1) «Берни дә түгел, мәшәкать тудырмый» мәгънәсендә. *Үзе әйтмешли, бу аңа чут та түгел.* А.Тимергалин; 2) «Дәрәҗәсе юк, әллә ни саналмый» мәгънәсендә. *Катык безнең авылда чут түгел.* М.Мәһдиев. **Чуты юк** Бихисап, бик күп. *Линиягә чыгып булмый, район үзәге белән миннән башка да сөйләшүчеләрнең чуты юк.* А.Хәсәнов

**ЧУТ** II *иярт.* 1) Бер тапкыр үбеп алганда ишетелгән тавышны белдерә

2) Сандугач һәм кайбер башка кошлар сайрап куйганда, бер тапкыр тавыш биргәндә ишетелгән авазны белдерә

**ЧУ́Т ИТҮ** *ф.* Чут сыман тавыш чыгару. *Гөлҗамал әби чут итеп [баланың] авызларыннан үпте.* М.Гали. *Чут та чут итеп сайравың үзәкләрне өзә.* Н.Хәсәнов

**ЧУТКА** *рәв. сөйл.* Кемнең дә булса исәбенә; берәүнең акча түләве исәбенә. *[Хәлил:] Госман абзый! Эч әйдә, минем чутка булыр...* Ш.Камал

**ЧУТЛА́У** I *ф. сөйл.* 1) Исәпләү, хисаплау. *[Мәймүнә:] Син миңа иске акча белән әйт, мин яңача чутлый белмим.* А.Гыйләҗев. *Эш күп, диген, имза чутлыйсы бар, Монда килеп борчып йөрмәсен!* Аманулла

2) Кем яки нәрсә турында берәр фикердә булу; уйлау. *Немецлар безне азиат дип, түбән сортлы раса дип чутлыйлар икән – дөресме?* А.Тимергалин. *Сез бит мине исәргә чутлыйсыз.* Н.Гыйматдинова

◊ **Чутлап кына** Бик сак рәвештә, санап кына. *Акчасын да тиенен-тиенгә чутлап кына тота.* Л.Ибраһим-Вәлиди

**Чутлап алу** Тиз генә чутлау. *Туган көннәрдә бер чутлап аласың да тагын чабасың.* Ш.Галиев

**Чутлап бару** Эзлекле рәвештә чутлау. *Башка төрле барласак, Бишәрләп чутлап барсак, Шулай ук арта бер хат.* Р.Нуруллин

**Чутлап бетерү** Барысын да чутлау, ахыргача чутлау. *Өегезгә кайтып, харам акчаны чутлап бетергәчтен, тукта, бу егет төне буе керфек какмаган лабаса, дип, сезгә үзем ял юнәттем.* Т.Әйди. *Бәйләмдәге чәчәкләрнең санын чутлап бетерә торган да түгел сыман тоелды Мөниргә.* Л.Ибраһим-Вәлиди

**Чутлап җибәрү** Көтмәгәндә чутлау; тәвәккәлләп чутлау. *Шимбә юк безгә, якшәмбе юк. Һәр айга сигез көнне икеләтә түләүдән чутлап җибәрегез әле.* Б.Камалов

**Чутлап тору** Даими яки вакытлыча чутлау; әле, хәзер чутлау. *Акчаңның тиененә кадәр кая киткәнен карап, чутлап торырга хөкүмәт бар.* В.Гали. *Барысын да чутлап тора, Вакыт – яхшы бухгалтер.* Г.Гыйльманов. *Менә син уйлый торгансыңдыр инде, фәләнфәсмәтән, бу шофёрны кешегә чутлап торырга, дисеңдер.* К.Кара

**Чутлап чыгару** Чутлап, ахырда исәбен табу. *Математик бит, их исәпләячәк инде хәзер, хәтер шәп, бер айлык хезмәт хакын чутлап чыгара.* Р.Газиз. *Тәҗрибәле, күренеп тора: рас кына бер көтү мал-туарның карынындагы үләнне дә чутлап чыгарды бит, әй.* К.Кәримов

**Чутлый башлау** Чутларга керешү. *Без хәзер үзебезне кешеләр итеп чутлый башладык.* А.Вергазов. *Хисап төймәләрен чалт-чолт итеп чутлый башлыйлар.* В.Юныс

**Чутлый бирү** Бернигә карамый чутлау. *Мәгыйзь исә чутлый бирә, сөйли бирә ---.* М.Мәһдиев

**Чутлый тору** Һаман чутлау, әлегәчә чутлау. *--- колхоз кассасы зарплатаны күп итеп чутлый тора.* Г.Рәхим

**ЧУТЛА́У** II *ф.* Юнып шомарту (бүрәнәне). *Бүрәнә чутлаганда, Әтүтән йомычканы өйгә сылап эшләнгән лапаска тутырып барган иде.* Ә.Галиев. *Аз гына балта тотып чәкүшкә юна алган, бүрәнә чутлый белгән кешеләр --- Зәйгә килделәр.* А.Гыйләҗев // Бүрәнәдән салына торган өйнең эчке стеналарын юнып шомарту. *Өй салуның ние бар: мүклисе дә чутлыйсы.* Әйтем

**Чутлап бетерү** Бик нык чутлау; тулысынча чутлау. *Өй бүрәнәләренең башларын йомычкага дип чутлап бетергәннәр.* М.Әхмәтҗанов

**ЧУТСЫЗ** *с. сөйл.* **1.** Исәпсез-хисапсыз, бик күп, исәпсез, санап бетергесез. *Чутсыз гомер берәүнең дә юк.* А.Гыйләҗев. *Авылда күрешәсе туган-тумача чутсыз икән, һәммәсе дә Бәдретдинне сагынган.* Н.Гыйматдинова

**2.** *рәв. мәгъ.* Бик нык, чамасыз. *Сөйли торгач, чутсыз мавыгып, көтү кайтып беткәнен, ала кәҗәсенең үтеп киткәнен күрми калды.* М.Маликова

**ЧУ́Т-ЧУТ** I *иярт.* Сандугач һәм кайбер башка кошларның сайрау тавышын белдерә. *Бик матур кояшлы озын көннәр иде, җылы, җилсез, йомшак төннәр, шәһәр бакчаларында сандугачлар да чут-чут сайрый иде әле.* Ә.Еники. *Сандугач-былбыллар чут-чут сыздыралар.* А.Гыйләҗев

◊ **Чут-чут сайрау** Телгә салыну, алдашу, мактану

**ЧУ́Т-ЧУТ** II *иярт.* Кемне дә булса кабат-кабат суырып үпкәндә чыккан тавышны белдерә; чуп-чуп. *Кысып-кысып кочаклап, аның ике бит очыннан чут-чут үбеп алды, чәчләрен һаман шулай иркәләп, кайнар тәне белән Сәлимгә елышты.* С.Поварисов. *Гуля, сыңар кулы белән киң кырлы эшләпәсен тотып, апаның яңагыннан чут-чут итеп үбеп алырга да өлгерде.* Р.Зәйдулла

**ЧУ́Т-ЧУТ ИТҮ** *ф.* Шундый аваз чыгару. *Кинәт Акбулатов баш очындагы ботакта ниндидер кошчыкның чут-чут итеп сайравын ишетте.* Г.Әпсәләмов

**ЧУ́Т-ЧУТ КИЛҮ** *ф. к.* **чут-чут итү**. *Куак ботагына кунган Сандугач, сөйгәнен, балаларын иркәли-иркәли, чут-чут килә.* Н.Сәйяр. *Менә песнәк чут-чут килеп узды.* М.Сафин

**ЧУТЫЛДАТУ** *ф.* Чут-чут иткән кебек тавышлар чыгару. *Абый, шаккаткыч чыгамы, дип көлеп җибәрә, аннан, инде тагын да шәбәебрәк, яңа көйләрне чутылдатырга тотына.* Р.Рахман. *Алар берөзлексез чутылдатып сайрамыйлар, шулай да сирәк-мирәк бер-беренә дәшәләр – үзләренә пар эзлиләр.* Р.Кәрами

**Чутылдата башлау** Чутылдатырга тотыну

**Чутылдатып алу** Аз гына, кыска гына ара чутылдату

**Чуталдатып җибәрү** *к.* **чутылдата башлау**

**Чутылдатып тору** Әледән-әле яки даими чутылдату; әле, хәзер чутылдату

**ЧУТЫЛДА́У** *ф.* Чут-чут итеп сайрау (сандугач һәм кайбер башка кошлар тур.). *Я ул бер вакытка кыска-кыска итеп чутылдый, я шул арада ничәмәничә борылышлар ясап, сызгыруга күчә.* Г.Галиев. *Егет-сандугачның сайравы ишетелмәгәч, тагын чутылдап сайрап китә, тагын тына, тагын тыңлый. Тагын көтә, тагын чутылдый.* З.Зәйнуллин

**Чутылдап алу** *к.* **чутылдап кую**. *Җырчы тын алганда, гармун уйнап торган шикелле, Әхмәт җырламый торганда, аның моңын дәвам иткәндәй, як-якта калынлы-нечкәле кыңгырау, шөлдер чыңлап куя, әрәмәдә сандугачлар чутылдап ала.* Г.Бәширов

**Чутылдап җибәрү** *к.* **чутылдый башлау**. *Сандугачлар болай сайрый: башта әллә кайдан караңгыдан ата сандугач очып килеп ботакка куна да чутылдап җибәрә.* Г.Әпсәләмов. *Тирә-юньдәге барча тавышны күмеп, таң чыпчыгы чутылдап җибәрде.* М.Хәбибуллин

**Чутылдап кую** Аз гына, кыска гына вакыт чутылдау. *Агач башларында аратирә кошлар чутылдап куя.* Г.Бәширов. *Аларның чыр-чуын басарга теләгәндәй, оя өстендәге пар сыерчык, канатларын кага-кага, бертуктаусыз сайрый, күршеләрнең тирәгендә сандугач чутылдап куя, ерактан сирәк-мирәк күке кычкырганы ишетелеп китә...* Ф.Садриев

**Чутылдап тору** Даими чутылдау; хәзер чутылдау

**Чутылдый башлау** Чутылдарга тотыну. *Һичнәрсәгә исе китмәгәнлеген белдерергә теләсә, я җырлый, я чутылдый башлый ул.* Р.Рахман

**ЧУТЫЛДАШУ** *ф. урт. юн. к.* **чутылдау**. *Тирә-ягымда сары җикәннәр тирбәлә, кошлар чутылдаша, әкияттәгедәй гүзәл күбәләкләр очып йөри.* Г.Якупова. *Үлән араларында кырмыскалар мәш килә, куакларда төрле кошлар оя кора, сандугачлар чутылдаша, күкеләр кычкыра.* Г.Сабитов

**Чутылдаша башлау** Чутылдашырга тотыну

**Чутылдашып тору** Даими чутылдашу; хәзерге вакытта, әле чутылдашу

**ЧУТЫНА** *рәв. сөйл.* **1.** *к.* **чутка**. *Аннары кайсыдыр, идарә чутына яздырып, кибеттән бер шешә аракы алып килде, ямаулы айгырның башын югары күтәрттеләр дә борын тишегеннән аракы койдылар.* М.Мәһдиев

**2.** *бәйл. функ. сөйл.* Карата, турында. *Киңәш чутына килгәндә, минем грамыт ягы бик чамалы.* А.Гыйләҗев

**ЧУТЫНДА** *бәйл. сөйл.* Турында, хакында. *Минем сезгә килүемнең төп сәбәбе дә, улым, шулар чутында.* Т.Гыйззәт

**ЧУТЫННАН** *рәв. сөйл.* **1.** *к.* **чутка**. *– Давай, укы, калхуз чутыннан укытабыз үзеңне! – дип, тиешле кәгазьләрен дә әзерләп бирде.* В.Нуруллин

**2.** *бәйл. мәгъ. к.* **чутында**. *Гәзиттә алпутларның җирләрен бүлү чутыннан берәр яңа сүз бармы әллә?* Г.Бәширов

**ЧУТЫР** *и.* **1.** 1) *иск.* Шадра

2) Кояшта кызынып каралган, тумыштан яки башка сәбәптән булган тут. *Инде эшкә чыкмыйча туры киң күлмәк киеп йөрүче, битләренә кара чутыр ябышкан яшь хатыннар да күренә.* М.Мәһдиев. *Икесе дә чутыр кебек яндырып торган чем-каралар.* А.Хәлим

**2.** *с. мәгъ.* Каратутлы. *Кояшта янган чутыр кара тән.* Р.Сәгъди

**ЧУФА** *и. исп. < гар. бот.* Күрәнчәләр семьялыгыннан тамырындагы кечкенә бүлбеләре азык итеп кулланыла торган күпьеллык үлән үсемлек, җир бадәме. *Җир миндале – чуфа, татлы бәрәңге – батат, момордика, мелотрия (Африка кыяры), тел белән әйтеп бетерә алмый торган тагын әллә нинди яшелчәләр үстерә ул.* Шәһри Казан

2) Шул үсемлекнең бадәм чикләвеге тәмен хәтерләтә торган ашарга яраклы бүлбесе

**ЧУХУР** *и. фар. иск. сөйл.* 1) Берәр урында даими яшәгән гади кеше, мещан. *Казан чухурлары белән берлектә, Николай патша рәсемен күтәреп, «Яшәсен падишаһы әгъзам хәзрәтләре!» дип, Казан урамнарында демонстрация ясап йөргән Галимҗан хәзрәт әлеге революция хәрәкәтенә катнашкан шәкертләргә каршы кискен чаралар күрә башлады.* З.Бәшири. *Юк, аның төп дошманы – асылда, кара халык, горфи, чухур, гавам, хәтта аның үз якыннары.* А.Тимергалин

2) Тар карашлы, вак мәнфәгатьләр белән яшәгән кеше. *Арабызда искегә ябышып ятучы кадими бәндәләр бүген дә җитәрлек. Үз бистәләреннән арыны күрмәгән һәм күрергә дә теләмәгән кадими чухурларның иң четерекле соравы мондый: космоста безнең ниебез калган?* А.Тимергалин

**ЧУЧКА** *и.* 1) Дуңгыз. *Аннары һәр көнне төшке чәй вакытында Рәҗәпов абыйга азык кибетеннән ак булки белән чучка ите алып кайтып бирә идем.* Ә.Еники. *Сөйләп кенә калмады, калхуз исеменнән ике чучка баласы да бүләк итте.* Р.Зәйдулла

2) *хурл.* Шапшак кеше

3) *күч. гади с.* Хурлау, тиргәү сүзе буларак кулланыла. *Тыныңны чыгарма, чучка!* К.Тинчурин. *Ишетәсеңме, чучка хатын, яртысы аныкы!* Н.Гыйматдинова

◊ **Чучка борын** *гади с.* Хурлау, тиргәү сүзе. *Мин сиңа, чучка борын, иптәш түгел, ә гражданин следователь булам.* З.Зәйнуллин. **Чучка колак** *к.* **чучка борын**. *Син нәрсә сөйләнеп йөрисең, чучка колак?* Т.Гыйззәт. **Чучка танау** *к.* **чучка борын**. *Нигә килми чучка танау, стражник, ришвәтче, сукин урәдник?* Т.Гыйззәт

**ЧУЧКАЧЫЛЫК** *и. сөйл.* Дуңгызчылык. *Сарыкларын бетереп, чучкачылыкка күчүчеләр, алай иттереп тә отучылар юк түгел.* К.Тимбикова. *Аннан, аракы җитештерүдән калган апара, арыш боламыгы татар дуңгызчылыгын ифрат та алга җибәргән, бүген һәр заводның үз чучкачылык комплексы бар икән.* А.Хәлим

**ЧҮ** *ы.* 1) Кемгә дә булса туктарга яисә акрынрак эш итәргә кушуны белдерә. *«Тукта, тукта, җитте, чү!»* Г.Тукай. *Хәзрәт йомшак тавыш илә: «Чүеңез, җәмәгать, чү!»* Г.Ибраһимов

2) Кемнең дә булса игътибарын нинди дә булса тавышка яки берәр нәрсәгә

юнәлтү өчен кулланыла: «тыңла», «игътибар ит» дигән мәгънәне белдерә. *Чү, алар Идел киңлегенә чыгалар түгелме?* Г. Әпсәләмов. *Айгөл кочагында да маэмай-эт көчеге түгел, ә теп-тере бүре баласы, чү, саграк була күрсен.* А.Хәсәнов

**ЧҮӘК** *и.* Күннән яки башка йомшак материалдан эшләнгән үкчәсез җиңел һәм йомшак аяк киеме. *Баланың башына ак кәҗә мамыгыннан бәйләнгән йомшак, йөнтәс башлык, өстенә бик зур ике кара төймә белән каптырылган кыска гына сырма кидерелгән, аякларында исә өр-яңа нәни генә кызгылт чүәк иде.* Н.Фәттах. *Миңҗамалдан башкаларының аякларында кайсысының чүәк, кайсысының резин галуш иде.* З.Зәйнуллин

**ЧҮӘКЧЕ** *и.* Чүәк тегүче, чүәк тегү остасы. *Чүәкче Җамалетдин Казан арты Өбрә авылыннан.* М.Мәһдиев. *Хәлил чүәкчеләр белән Төркиядә булып кайткан иде.* Т.Галиуллин

**ЧҮБЕК** *и.* 1) Киндерне, җитенне һәм гомумән җепселле берәр нәрсәне эшкәрткәннән соң калган чүп, калдык, сүсәрән. – *Әлбәттә, шулай, – диде Николай, кулын чүбек белән сөртәсөртә, – техник контроль – формальность кына ул.* Г.Әпсәләмов

2) Нәрсәнең дә булса эченә тутырыла, кыстырыла, салына торган йомшак күпшәк материал. *Вәли түбәсе ертылып, эчендәге чүбекләре чыгып торган колаклы бүректән, култык аслары сүтек озын билле бишмәттән, ялана-як.* Ә.Еники. *Йомшак уенчык чүбеге*

3) Кайбер күшәүче хайваннарда ашказанынннан авыз куышлыгына килеп яңадан икенче мәртәбә күшәлә торган азык, чәйнәвек, күшәм. *Авызындагы чүбеген күшәп, як-ягына каранып барган дөяләр кәрваны узып киткәч, киң һәм буш сахра тагын үзенең серле һәм моңлы тынлыгында тирбәлә калды.* М.Галәү

◊ **Чүбек җанлы** *гади с.* Вак-төяк, әһәмиятсез нәрсәләр белән генә кызыксына торган. *[Гөлзадә:] Чүбек җанлы хатын-кызлар, камыр йөрәкле ирләр, калай күңелле ата-аналар безнең җәмгыятьтә булмаска тиешләр!* Р. Ишморат. **Чүбек чәйнәү** *гади с.* Буш сүз сөйләү, әһәмиятсез сүз сөйләү. *Бату кулына әсирлеккә төшкән вак кенәзләр, әлеге кала турында юлда чүбек чәйнәп, күпме баш катырды!* В.Имамов. *Сәгать ярым чүбек чәйнәп, бер рәтле фикер дә әйтмичә, Хәмзә Хәерчи трибунадан төшеп китте.* Г.Афзал

**ЧҮБЕКБАШ** *и. гади с.* Аңгыра, миңгерәү, ахмак кеше. *Ул чүбекбашны күзәтеп, өйрәтеп тормасаң...* А.Гыйләҗев. *Ниткән сүз ул, ул йортта яшисем килми, имеш, җитмәсә, анаң да, чүбекбаш, үз сөягебез үзебездән артык түгел, кайт, кызым, үз өеңә, дип әйткәндер әле.* Г.Галиева

**ЧҮБЕКЛӘНДЕРҮ** *ф. сөйл.* Чүбек рәвешенә кертү, чүбеккә әйләндерү; тетеп бетерү. *Резидә дә, ниһаять, беренче бүлкәне чүбекләндереп, калдык-постыкларын миңа сузды.* Ф.Шәфигуллин

**Чүбекләндерә бару** Торган саен чүбекләндерү

**ЧҮБЕКЛӘНҮ** *ф. сөйл.* Чүбек рәвешенә керү; чүбеккә әйләнү; тетелеп, сүсәреп бетү. *Болай иткәндә кәгазь чүбекләнми, шулай да, тырнак йөзе белән «яралы урынны» ышкып, шомартып аласың.* М.Галиев

**Чүбекләнә бару** Торган саен чүбекләнү

**Чүбекләнеп бетү** Тәмам чүбекләнү. *Ләкин ул юка, начар кәгазьләр, анда йөри торгач, таушалып, тиз арада чүбекләнеп бетәләр, карандаш язуы таный алмаслык хәлгә килә.* Ш.Маннур. *Кайберәүләр кулларына чите чүбекләнеп беткән иске яисә өр-яңа китаплар тотып, туп-туры Нәсим бүлмәсенә уздылар.* Н.Фәттах

**ЧҮБЕКЛӘ́Ү** *ф.* 1) *сөйл. к.* **чүбекләндерү**

2) Бутау, буташтыру. *Фикерен аламаландырып, чүбекләп, анык кына әйтеп бирә белмичә азаплый торган старшина Лагуньга киная булды бугай бу.* М.Галиев

**Чүбекләп бетерү** Тәмам чүбекләү

**ЧҮГӘЛӘП** *рәв. к.* **чүгәли-чүгәли**. *Килмәсен беркөнне, «ярыйм!» дип, чүгәләп-чүгәләп биергә!* Р.Фәйзуллин. *Үлчәвенең үрдәкләре Чүгәләп биеп тора.* Ш.Галиев

**ЧҮГӘЛӘ́Ү** *ф.* Тезләрне бөгеп, өлешчә яки тулысынча аяк табаннарына таяну; чүмәшү, чүгү. *Сүнеп беткән учак янында, чүгәләп, Әхәт абый тәмәке тартып утыра иде.* Г.Бәширов. *Стена буена чүгәләп, мич эчен караштырып утырган Гөлбану кинәт кенә сагайды.* М.Хәсәнов

**Чүгәләп алу** Бер тапкыр чүгәләү. *Онык бик күп чүгәләп ала.* Ш.Галиев

**Чүгәләп тору** Чүгәләгән хәлдә булу. *Ул, ни карарга килергә белмичә, селкенергә дә куркып, һаман кычыткан арасында чүгәләп тора иде.* А.Гыйләҗев

**ЧҮГӘЛИ́-ЧҮГӘЛИ** *рәв.* Аякларда басып торган килеш, тезләрне бөгеп, аякларны алмашлап алга ташлап. *Ул яшел үлән кыякларын сыта-сыта биеде, учларын шап-шап чәбәкләп, чүгәличүгәли, аланны йөз әйләнде.* А.Гыйләҗев. *Ирләр чүгәли-чүгәли бии, ә хатын-кызлар, өстәлнең бер башына җыелган да, бер-берсен бүлә-бүлә нидер сөйләшә.* Р.Вәлиев

**ЧҮГӘ-ЧҮГӘ** *рәв. сөйл. к.* **чүгәли-чүгәли**. *Бии кояш, чүгә-чүгә бии.* Р.Әхмәтҗанов. – *Кызгана күр, батыр, безне үзең белән ал, – дип, көтүчеләрнең җиргә чүгә-чүгә ялваруын күрүгә, Сәет елмаеп башын какты.* В.Имамов

**ЧҮГЕНҮ** *ф. диал. к.* **чүгү** (*1, 2 мәгъ.*). *Моннан соң һәр икесе Рәсүл галәйһиссәламнең алдына килеп чүгенделәр.* К.Насыйри. *Ул килеп җиткәндә, кара туры арт аякларын алга сузып, чүгенгәндәй итте.* В.Нуриев

**ЧҮГЕРМӘК** *и. диал.* 1) Кечкенә, әмма тирән күл. *Әгәр дә елга үзенең агымында текә булып түбән ашалып төшкән урынны очратса, су, аннан агып төшеп, шарлавык яки чүгермәк хасил итәдер.* З.Шакиров

2) Юлларда тәгәрмәчләр гел бер турыдан узганга тирәнәеп калган эз; колея, эзәк

**ЧҮГҮ** *ф.* 1) Чүгәләү. *Ул, тиз генә бала алдына чүгеп, битләреннән, күзләреннән үбә башлады.* Г.Әпсәләмов

2) Тезләргә басу, тезләнү. *Туңгак алып киез өстеннән бер-ике адым гына атлады да тагын бикә алдына тез чүкте.* Н.Фәттах. *Читлегенә керсәм, алгы аякларына чүгә.* А.Хәсәнов

3) Баскан җиреннән, аякларын бөгеп, җиргә утырмыйча, шулар өстенә урнашу. *Шушы сарай астына дөя чүкте, Төшеп, дөя йөзен сыйпады-үпте.* Дастан

4) Биеклеге, буе кимү; җиргә сеңү, иңү. *Хәзер ул чүккән, черегән, бер урыны бүлтәеп калыккан, икенче урыны чокыраеп кергән.* Ф.Садриев. *Өй хәтта чүккән дә сыман.* Ә.Әминев

5) *диал.* Чигенү, артка китү. *Сыбай да каршында ниндидер тутыйкош торуын чамалады бугай, бер карышка чүккән кебек булды.* В.Имамов

6) *күч.* Төшү, иңү; кабу. *Мәрьям күл буеннан алачыкка кайтып кергәндә, җиргә караңгылык чүгә иде инде.* Ш.Камал

**Чүгеп алу** Азга гына чүгү. *Яфракларга Шыбыр-шыбыр яңгыр ява. Яшел клавишлар батып-чүгеп ала.* Р.Харис. *Ул чүгеп-чүгеп ала!* Р.Корбан

**Чүгеп кую** Бер тапкыр чүгү. *Монысы печән кибәнедәй зур гәүдәле иде, аның авырлыгыннан арба чүгеп куйды.* В.Имамов. *Кайберләре бер-ике адым арткарак та чүгеп куйды әле.* Г.Гыйльманов

**Чүгә бару** Торган саен чүгү. *Баһадирдай гәүдә дә әкренләп җиргә чүгә барган күк тоела иде.* А.Әхмәтгалиева

**Чүгә башлау** Чүгәргә тотыну. *Кинәт ул чүгә башлады һәм, яртылаш чүккән килеш бераз торгач, лып итеп авып төште.* Г.Әпсәләмов. *Ул, Майяны күрүгә, күзләрен шар ачып катып калды, аннары акрын гына артка чүгә башлады.* Г.Гыйльманов

**Чүгә төшү** Бераз чүгү. *Байтак елларны иңенә салганлыктан беркадәр җиргә чүгә төшкән таш йорт иде бу.* В.Имамов. *Узем дә, баскан җиремдә чүгә төшеп, тирән уйга калдым.* А.Хәсәнов

**ЧҮКЕЛДӘТҮ** *ф. сөйл.* 1) *төш. юн. к.* **чүкелдәү**. *Көне-төне чүкелдәтә, ди, бу.* Г.Бәширов

2) *к.* **чүкелдәү**. *Рәсимәсе белән Югары очта чүкелдәтеп яшәп яталар. Ни өчен чүкелдәтеп, чөнки малае – алачыкта тимерче.* Р.Газиз

**Чүкелдәтеп алу** Бераз чүкелдәтү

**Чүкелдәтеп кую** Кинәт кенә яки бер тапкыр чүкелдәтү

**Чүкелдәтеп тору** Әле, хәзер яки әледән-әле чүкелдәтү

**ЧҮКЕЛДӘҮ** *ф.* Чүкү, тимергә суккалау; бәргәләп чыңлаган тавыш чыгару. *Ә миңа, әнә, аларның бер бүлмәсе дә бик җитә: язу машинкам белән көн-төн чүкелдәп утырам мин шунда...* М.Вәли-Барҗылы. *Тимерче алачыкта чүкеч белән чүкелди*

**Чүкелдәп тору** Гел, һәрвакыт чүкелдәү; хәзер чүкелдәү. *Язу машинкасы көне-төне чүкелдәп тора*

**Чүкелди башлау** Чүкелдәргә тотыну. *Ир чүкеч белән чүкелди башлады*

**ЧҮКЕЛМӘ** *и.* Чүкеп яки штамплау юлы белән ясалган эшләнмә; *русчасы:* **штамповка, чеканка**. *1975 елның 10 сентябрендә беренче номерлы пресслар цехында беренче кайнар чүкелмә штампланды.* Казан утлары. *Нәфис чүкелмә*

**ЧҮКЕЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **чүкү**. *Печәнгә чыгасы авылның чүкелеп куелган чалгысы.* З.Мансуров. *Тазартканнан соң, аның чүкелеп ясалган борынгы йозак икәнлеге ачыкланды.* А.Хәлим

2) Чүкүгә бирелү. *Тимер – пластик металл: ул яхшы чүкелә.* Химия

**ЧҮКЕЛҮЧӘН** *с.* Чүкүгә җиңел бирелүчән, яхшы чүкелә торган. *Графит, формасына һәм аның барлыкка килү шартларына карап, чуен соры, нык һәм чүкелүчән була.* Төзү материаллары. *Бригадасына корыч һәм чүкелүчән чуен кою корпуслары нигезләрен бетонлауда көне-төне тырышырга, җитештерүчәнлекне күтәрергә, сыйфатны яхшыртырга туры килә.* Якты юл

**ЧҮКЕЛҮЧӘНЛЕК** *и.* Чүкелүчән булу үзлеге, чүкүгә бирелү дәрәҗәсе. *Алюминийның чүкелүчәнлеге бик югары.* Химия

**ЧҮКЕРДӘШҮ** *ф. диал. к.* **чөкердәшү**. *Ләкин җәй көннәрендә бу гаиләгә гел генә бергә булырга, чүкердәшеп, бергә вакыт үткәрергә туры килми.* Ә.Еники. *Таңсылу алып кайткан тәмтомнар белән бергә чүкердәшеп чәй эчтеләр.* Ф.Яруллин. *Икесе дә зур укулар бетергән, чүкердәшеп яшәрләр.* Н.Гыйматдинова

**ЧҮКЕРҮ** *ф. диал.* Сугу, бәрү. *Тукмагы белән чүкереп Һәлак кылып ташлады.* Дастан

**ЧҮКЕРЧӘ** *и. диал. к.* **шыртлака**

**ЧҮКЕЧ** *и.* 1) Берәр нәрсәне кагып кертү, турайту, яньчү яисә берәр нәрсәгә сугу өчен, туры почмак ясап сапка утыртылган, төрле формадагы агач яки металл борысчыктан гыйбарәт эш коралы. *Таймасның чүкечне җәйсыз тотуын, бер сугасы җиргә биш сугып азаплануын, кадакларны кәкрәйтеп бетерүен күрмичә калмадылар.* А.Тимергалин. *Узе белән балта, көрәк, пычкы, чүкеч, кыскыч, төйгеч, кискеч һәм башка кораллар алды.* А.Хәлим

2) Невропатологның нерв реакциясен тикшерә торган шундый формадагы коралы. *Тезләренә чүкеч белән сугалар, авызын ачып карыйлар, күрү сәләтен тикшерәләр.* З.Хәким. *Соңга калып килгән кыз йөгергәнгә охшый, аның дулкынланган алмалары егетнең күкрәгенә военкоматтагы табибның резин чүкече кебек суга.* Р.Газиз

3) *анат.* Урта колактагы сөякчекләрнең берсе. *Урта колак куышлыгында өч ишетү сөякчеге бар: аларның берсе – чүкеч – барабан пәрдәсенә терәлеп тора.* Анатомия

4) *к.* **чүкеччек** (*2 мәгъ.*)

5) Пластинкалы көбә күлмәкнең чүкеп ясалган аерым чүкелмәсе

◊ **Чүкеч бәрделәр диярсең** *к.* **чүкеч белән бәргәндәй**. *Башына чүкеч бәрделәр диярсең, уйлары буталды.* **Чүкеч белән бәргәндәй** Кешегә, аның рухи халәтенә бик нык тәэсир итү турында. *Чүкеч белән бәргәндәй, колагында һаман-һаман бер сүз кабатланды.* В.Имамов. **Чүкеч белән сандал арасы** Бер-беренә дошман булган ике як арасында калуны, авыр хәлдә булуны белдерә. *[Нәгыймь:] Мин хәзер чүкеч белән сандал, яисә ике ут арасына кереп барганымны ачык сизәм.* Ш.Камал. **Чүкеч кебек** Нык, чыдам. *Чүкеч кебек таза егет вакытында бай атларын карап уздырган көннәрен уны белән, йөзе белән кайтарды ул.* М.Мәһдиев. **Чүкечтән сату** Аукционда сату. *НЭП ахырында әтиләренең түләнмәгән налогы өчен [өйне] чүкечтән сатып җибәрделәр.* Ә.Еники. **Чүкеч сугып сату** *к.* **чүкечтән сату**. *Аның кибетен чүкеч сугып саттылар.* Н.Дәүли

**ЧҮКЕЧБАЛЫК** *и. зоол.* Акулачалар семьялыгыннан башы чүкечкә охшаган балык; *русчасы:* **рыба-молот**

**ЧҮКЕЧБАШ** *и. зоол.* Чүкечбашчалар семьялыгыннан очлы томшыклы, башы чүкечне хәтерләткән кош; *русчасы:* **молотоглав**

**ЧҮКЕЧЛӘҮ** *ф. к.* **чүкү** (*1, 2 мәгъ.*). *Чүкечне бик каплыйдыр, ягъни чүкечләп никадәр җәйсәң дә җәеләдер, ягъни йомшак мәгъдәндер, һәр ел Русиядә 645 пот чамасында алтын чыгадыр.* К.Насыйри

**ЧҮКЕЧЛЕ** *с.* 1) Чүкече булган; чүкеч урнаштырылган. *Ләкин әлеге уракчүкечле тәңкәне бик үк өнәп бетермәгән кеше дә булды.* Т.Нурмөхәммәтов

2) Аерым пластинкалардан, чүкелмәләрдән ясалган. *Мең чүкечле көбәне Кайда кидең, Норадын?* Дастан

**ЧҮКЕЧЧЕ** *и.* Чүкеч белән эшләүче, чүкеч сугучы эшче. *Сугыш башланганда, ул әле үсмер генә була, әмма инде авыл тимерчелегендә чүкечче булып эшли.* Мәдәни җомга

**ЧҮКЕЧЧЕК** *и.* 1) Кечкенә чүкеч. *Аларның өенә барып керсәң, сәке йөзлегендә нинди генә кораллар юк: кечкенә чүкеччекләр, боргычлар, шөрепләр, гармун телләре, җиз калай кисәкләре, еллар буе киптерелгән агач планкалар.* Р.Батулла

2) Кайбер механизмнарда, уен коралларында кечкенә генә бәрү җайланмасы. *Рояль чүкеччеге*

3) *анат. к.* **чүкеч** (*3 мәгъ.*). *Урта колак һава тулган куышлыктан гыйбарәт. Анда өч ишетү сөякчеге бар. Аларның берсе – чүкеччек, ул колак пәрдәсенә терәлә, икенчесе – сандал сөяк, ул эчке колакка алып кергән овал тәрәзә пәрдәсенә орынып тора.* Биология

**ЧҮКТЕРҮ** *ф. йөкл. юн. к.* **чүгү**. *Чөнки тимердән корал эшләп була, ә кораллы халыкны, әгәр ул баш күтәрә калса, тез чүктерүе авыр.* З.Мурсиев. *Филне чүктерү*

**ЧҮКҮ** *ф.* 1) Кызган металлга тиешле форма бирү өчен чүкеч белән сугу, бәрү. *Ул һәр көн иртән шәһәр читендәге алачыгына бара, ут кабыза, күрек тарта, бакыр чүки.* Р.Батулла. *Тәкъдир алачыгы нидер чүки: Әллә калкан, әллә үткер хәнҗәр?* Ф.Яхин

2) Шул юл белән тимердән нәрсә дә булса ясау. *Безнең дипломатия чат саен «мир» диде, ә хөкүмәтебез мыштым гына көне-төне корал чүкеде.* Ә.Еники

3) Чалгының йөзен чүкеч белән бәреп юкарту, таптау. *Мин кичтән чалгымны чүкеп, әзерләп куйган идем.* Г.Ибраһимов. *Беренче Герман сугышында сыңар аягын калдырып кайткан Фәхразый карт кына чалгы чүкеп өлгертә алмагач, аңа ярдәмгә ике коданы – Гаптелихсан белән Хәнифне дә куштылар.* Н.Әхмәдиев

4) Металл эшләнмә өстенә суктырып, рельефлы сурәт төшерү. *Чүкеп ясалган рәсем*

5) *күч.* Бик нык тырышып, һиммәт күрсәтеп берәр нәрсәне әзерләү, булдыру, китереп чыгару. *Баһадирдай Москва эшчеләре Үлем чүки анда дошманга.* Ш.Маннур. *[Хәйдәр:] Җәүдәт абый, сугыш миннән икенче кеше чүкеп чыгармады чыгаруын, шулай да мин хәзер бөтенләй ук элекке Хәйдәр түгелдер, ахрысы.* Г.Бәширов

6) *күч.* Үтерү, атып үтерү. *Әнә бит аның кодасы ике снайперны чүкеп төшергән!..* А.Гыйләҗев. *Башкалар колан көтүләрен Чин диварлары ягыннан куып китерергә тиеш, ә Чыңгызхан, үз нияте буенча, тайларны, бияләрне куак арасыннан чүкеп кенә утырмакчы иде.* В.Имамов

**ЧҮ́К-ЧҮК** *ы.* Дуңгызларны чакыру сүзе. *Бу хайваннар, борын сеңерләрен тишеп бәйләнгән нечкә генә җеп белән, һич тә карышмыйча килделәр. Кәрим карт берсен тартты да: – Чүк-чүк! – диде.* Г.Ибраһимов

**ЧҮЛ** *и.* Явым-төшем бик аз, үсемлекләргә бик ярлы булган яки алар бөтенләй булмаган сусыз, комлы географик зонадагы зур мәйдан, өлкә. *Колан кактан җирәнсә, как таба алмый чүлдә үлер.* Әйтем. *Без чүл уртасындагы юлдан барабыз.* М.Мәһдиев

**ЧҮ́Л БҮРЕСЕ** *и. зоол. к.* **шакал**. *Чүл бүресе сыман үрсәләнеп, Кызганыч тәмамланыр тормыш.* А.Нәҗми. *Гөлзифа апаның әүвәл ияге олы бияләй сыман салынып төште, аннары карашы тундрада чүл бүресе күргән шикелле кисәк сәерләнде.* В.Имамов

**ЧҮЛЕКМӘ** *и. диал.* Коедан су алу өчен, багана башына беркетелгән баулы озын колга; сиртмә. *Уң кулда – кое, чүлекмәсе күтәрелгән.* Ф.Бурнаш

**ЧҮЛЛӘ́Ү** *ф. диал.* Сусау. *Үтеп бара гомер кәрваны чүлләп, Кәеф-сафа белән үтсә көнең – шәп.* Г.Хәйям

**ЧҮЛЛЕК** *и. иск. к.* **чүл**. *Каргалы Вәлид ишанны бервакыт алмага бардым. Алып килгәндә, 60 чакрым озак сусыз чүллек җирдән килдек.* К.Насыйри. *Июль аеның тәнне генә түгел, җанны да өтәрлек эссе кояшы астында чүллек аша 500 чакрымга якын юл үтәргә кирәк аларга.* Кызыл таң

**ЧҮЛЛИ** *и. диал.* 1) Литрның дүрттән бер өлешенә, чирек литрга тигез сыеклык үлчәве

2) Шундый күләмдәге сыеклык сыешлы шешә. *Базардан кайтышлый Миргаяз абыйның бер чүлли аракы алуы турында хәбәр бөтен авылга таралды.* М.Хуҗин. *Бер ярты үзенә генә күп, ә чүлли (чәки) әз кебек.* Т.Нәҗмиев

**ЧҮЛМӘК** *и.* **1.** 1) Катык-сөт һ.б.ш. салып кую, мичтә ризык әзерләү өчен, балчыктан яндырып ясалган, төбе тар-рак йомры савыт. *Май чүлмәге – тышыннан, булыр кеше – эшеннән.* Мәкаль. *Көтү чираты бүген аларда икән, шушы чүлмәк белән көтүчеләргә кырга аш илткән булганнар.* В.Нуруллин

2) Шундый ук максатларда файдаланылган, башка материалдан эшләнгән шундый савыт. *Анда чиләк сыешлы чуен чүлмәк белән итле ботка пешеп утыра иде.* З.Зәйнуллин. *Кечкенә чуен чүлмәк кулыннан төшеп киткән икән.* Ә.Моталлапов

3) Шундый савытка салынган ашамлык. *Сәгыйть ул үзе генә булганда чирек чүлмәк эчә.* А.Шамов

4) Гөл утырту өчен, өскә таба киңәеп киткән, гадәттә төбе тишекле савыт. *Шулчак, Озын буйның нәкъ алдына диярлек, каяндыр гөл чүлмәге килеп төште дә челпәрәмә килде.* Л.Лерон. *Бинаның диварларына обой ябыштырылган, карават, кәнәфи, комод, телевизор бар, чүлмәктә гөл үсеп утыра.* Сабантуй

5) *сөйл.* Тактачык, плитка рәвешендә балчыктан яндырып ясалган түбә ябу материалы; чирәп. *Әлбәттә, ул соңрак күпмедер яңартылган: 1436 елда түбәсе чүлмәк белән ябылган, 1530 елда аның чатыры башына сугышчы (карт Тоомас) кыяфәтендәге флюгер куелган, 1630 елларда чатыр өстеннән готик стильдә шактый биек манара калкытылган һәм флюгер да шуның башына күчерелгән.* Т.Әйди

**2.** *с. мәгъ.* 1) Яндырылган балчыктан эшләнгән. *Тишек-тошык түбәләрдә чүлмәк морҗалар тырпаеп тора.* М.Хәсәнов

2) Чирәп белән ябылган. *Кызыл чүлмәк түбәле, сырлап эшләнгән ак болдырлы, ак балконлы йортларга хәрби кешеләр кереп-чыгып йөри.* Г.Әпсәләмов. *Югары суд шәһәрнең үзәгендә, аскы каты колонналы, икенче каты тоташ ачык әйванлы, чүлмәк түбәле борынгы йортта урнашкан.* Т.Әйди

**ЧҮЛМӘК САТЫШ** *и.* Балалар уенының бер төре

**ЧҮЛМӘКЧЕ** *и.* Балчыктан яндырып савытлар ясаучы оста, чүлмәк остасы. *Аларның берсе – Корыч-Тимернең атасы Алып-Тархан, икенчесе – чүлмәкче Котылмыш, өченчесе бакырчы Юлай иде.* Н.Фәттах. *Кешеләр, Җил иясен ябу өчен, махсус эшләнгән чүлмәкне чүлмәкче сараеннан көчхәл белән күтәреп алып чыкканнар.* Г.Гыйльманов

◊ **Чүлмәкчедән күрмәкче** Берәүнең, башка кешегә ияреп, нинди дә булса эш-хәрәкәт башкарырга маташуына карата әйтелә. *Чүлмәкчедән күрмәкче икеөч хатын безгә иярде, аларга тагын ничәүдер кушылды, түгәрәкләнеп, базар ясадык.* А.Гыйләҗев. *Бер елны мин дә, чүлмәкчедән күрмәкче, туган көн уздырган булган идем, Ак әбием миңа беләзеге каймалы кызыллы-зәңгәрле бияләй бүләк итте.* Р.Батулла

**ЧҮЛМӘНЧЕК** *и. этн.* Яңгыр боткасы. *Алар, бергәләп, «Чүлмәнчек» дип аталган йола күрсәттеләр.* Туганайлар

**ЧҮЛМӘЧЛЕКИ** *и. этн.* Яңгыр теләү йөзеннән бер-береңә су сибешүдән гыйбарәт йола. *Чүлмәчлеки дә сүрелгән*

*булырга охшый. Ник дисәң, урамда тавыш-мазар тынган иде инде.* Г.Бәширов

**ЧҮМӘКЛӘШҮ** I *ф. диал.* Бәргәләшү, сугышу; талашу. *Күмәкләшкән яу кайтарган, чүмәкләшкән туй кайтарган.* Мәкаль

**ЧҮМӘКЛӘШҮ** II *ф. диал.* Чүмәшү. *Көткәннәр, көткәннәр дә машинага чүмәкләшеп утырган килеш йоклап киткәннәр, шуннан инде кабат уянмаганнар.* Н.Дәүли

**ЧҮМӘЛӘ** *и.* Түгәрәкләп һәм очлап өелгән, кибәннән күпкә кечкенә, печән, урылган иген яки салам өеме. *Урман аланында киерелеп печән чабарсың, без малайлар белән печән әйләндерербез, күбәләрбез, чүмәлә куярбыз.* А.Гыйләҗев. *Бер чүмәлә китергән саен, богыл биегәеп, Хәбир бабай югарырак күтәрелә бара.* В.Нуруллин

**ЧҮМӘЛӘМӘ** *рәв. диал. к.* **түбәләмә**. *Бер кырыйда зур-зур тартмаларда чүмәләмә өелгән цейлон чәе тора, бу кадәрле байлыкны минем гомеремдә дә күргәнем юк иде.* М.Галиев. *Карасалар, бер почмакта бишекле мотоцикл тора, аңа чүмәләмә яшь люцерна төялгән иде.* Х.Камалов

**ЧҮМӘЛӘ́САЛГЫЧ** *и. а.х.* Саламны, печәнне чүмәләләргә өя торган машина, җайланма

**ЧҮМӘШҮ** *ф. сөйл. к.* **чүгәләү**. *Руслан да озак сайланып маташмады, нәкъ мин әйткәннәрне кабатлап, каршыма чүмәште.* А.Әхмәтгалиева. *Ул инде бу йортның утыргычына чүмәште, тагын да бөрешеп, кечерәеп тынып калды.* Г.Әдһәмова

**Чүмәшеп тору** Хәзерге вакытта чүмәшү, билгеле вакытка чүмәшү. *Күзләренә иңгән явыз шатлыкны биек машинаның почмагында чүмәшеп торган Җирән генә күрде.* Т.Галиуллин

**ЧҮМЕРҮ** *ф.* 1) *диал.* Берәр савыт белән тутырып алу, сосып алу, чумыру (сыеклыкны). *Миңнулла каскасы белән салкын су чүмереп алды да туйганчы эчте, аннары битен юды.* Г.Әпсәләмов. *Ул сак кына адымнар белән өй эченә узды да сандык өстендәге чиләктән бер чүмеч су чүмереп алды.* А.Расих

2) *диал. к.* **чөмерү**. *Коры кием эләктереп алган Гарәфетдин чәй чүмерә.* Р.Газиз. *Алар килгәч, өстәлгә самавыр менде, тирләп-пешеп, бер-ике чынаяк кишер чәе чүмерделәр, мичкә тәгәрәткән бәрәңгеләре телеңне йотарлык тәмле иде.* Г.Әдһәмова

**ЧҮМЕЧ** *и.* 1) Сыеклык, аш һ.б.ш.ны сосып, чумырып алу өчен саплы савыт. *Ул Илсөяргә чүмеч белән су китерде.* Г.Гобәй. *Самавырын ут яктысына чыгарып, бакыр чүмеч белән су тутырды, күмер салды, мич алдында тезелеп торган вак-вак чыралардан өч-дүртне алып, шырпы кабызды.* А.Гыйләҗев

2) *тех.* Кайбер механизмнарда нәрсәне дә булса сосып, чумырып ала торган җайланма. *Мин кабинада утырган Фәрит абыйны күзәтәм. Бәләкәй генә, юка гына ул, ә нинди көчле техниканы үзенә буйсындыра. Бер рычагны тарта – чүмеч җиргә кадала, икенчесен бора – фәлән хәтле туфракны һә дигәнче күтәреп тә сала...* Д.Булатова. *АЭСның беренче реактор котлованын казыганда, экскаватор чүмече палеозой казналыгыннан мамонтның казык тешен суырып чыгара.* Г.Морат

**ЧҮМЕЧБАШ** *и. сөйл. к.* **чукмарбаш**. *Яфраклар салкынча, инде саргаеп киләләр, үзләреннән ләм, балык, чүмечбаш исләре бөркелә, бөтен гәүдәгә рәхәтлек иңә.* Көмеш кыңгырау

**ЧҮМЕЧГӨЛ** *и. бот. к.* **суҗыяр**; *русчасы:* **водосбор**. *Вак-вак ак чәчәкле, яфраклары чокырланып торган хуш исле чүмечгөлләр арасыннан чәчен уртадан аерып ике толым итеп үргән яшь кыз күренде.* Г.Әпсәләмов

**ЧҮМЕЧЛӘП** *рәв.* Чүмеч белән, чүмеч белән исәпләп. *Кибетләрдә хушбуйны чүмечләп сатмыйлар, ул сыра түгел.* К.Кәримов. *Беренче карашка кар бик нык ята әле, беркайда да чүмечләп-чиләкләп алырлык су күренми.* М.Маликова

**ЧҮМЕЧЛЕК** *и.* Кухняда чүмечләр куя торган урын яки савыт

**ЧҮННИК** *и. рус диал.* 1) Умарталарны кышкыга кую өчен җылы бура яки җир-йорт. *Закир абый башы белән чүнник ягына ымлады.* Г.Бәширов

2) *ялг.* Умарталык, умарталар куелган урын, бал корты хуҗалыгы. *Әнә моннан ярты чакрымда гына урман авызында чүнник бар.* З.Хәким

**ЧҮҢКӘЕШҮ** *ф. урт. юн. к.* **чүңкәю**. *Тар гына бүлмәдә балта эләрлек булып куе тәмәке болыты асылынган, өстәл артында чүңкәешкән өч ирне көчкә генә шәйләрлек иде.* Н.Гыйматдинова

**ЧҮҢКӘЙТҮ** *ф. йөк. юн.* **янтайту**. *Менә бармаклары чытырдап кысылды, һәм ул, башын акрын гына алга чүңкәйтеп, ике кулы белән берьюлы пеләшенә сукты.* Ф.Садриев

**ЧҮҢКӘЮ** *ф. диал. к.* **янтаю**. *Арба чүңкәйде*

**ЧҮҢКЕ** *с. диал.* Үтмәс. *Чүңке пычак*

**ЧҮҢКЕЛӘНҮ** *ф. диал.* Үтмәсләнү. *Кайчы чүңкеләнгән*

**ЧҮП** I *и.* **1**. 1) Өйдә, урамда һ.б.ш. урыннарда була торган ташландык, кирәкмәгән вак-төяк кисәкләр, калдыклар. *Сәлахның квартирасы тәртипсез тормыш белән яшәүче кешеләрнекенә хас иде: өстәлдә аш калдыклары, юылмаган тәлинкәләр, тәмәке төпчекләре, идән тулы чүп, урындыкларда төрле кием-салым чәчелеп ята, күбесе керле.* Г.Әпсәләмов. *Урамнары киң, таш түшәлгән, һичнинди чүп әсәре күренми, зәһәр ис сизелми.* В.Имамов

2) Берәр нәрсәне эшкәрткәндә барлыкка килгән вак кисәкләр, вак калдык. *Тирә-якны пычкы чүбе каплап алган.* А.Алиш. *Җитмәсә бит әле, ул салам, печән чүпләреннән биегәя бара.* А.Хәмзин

3) Нәрсәнең дә булса бер кечкенә кисәге, бөртеге; кечкенә бер чит нәрсә. *Күзгә чүп керде дә, тәрәзә яктысына килим дип калкынган идем.* А.Гыйләҗев. *Бүген түбәндә – хәрчәүнә, Тора күзгә кергән чүп кебек.* А.Хәлим

4) Культуралы үсемлекләргә үсәргә комачаулый, аларны чүпли торган кыргый үсемлек, чит үсемлек. *Ә бәрәңгеләре әле һаман да чүп эчендә утыра икән.* А.Хәлим. *Бер хатын, сабыен басу читенә утыртып куеп, башын да калкытмыйча чүп утый.* Г.Гыйльманов

5) Ашлык, җиләк һ.б.ш. бер иш нәрсәдә була торган ашарга яраксыз өлеше яки чит вак-төяк кушылма. *Төне буе җиләк чүбе чистарттык*

6) *куч.* Әһәмияте, кыйммәте булмаган, кирәкмәгән яки яраксыз нәрсә. *Секундлар нәрсә? Чүп! Безгә ракетный истребитель кебек ыргылырга кирәк, секундлар түгел, тәүлекләр артта калсын!* Г.Әпсәләмов. *Көлә-көлә әйттең! Димәк, минем борчылуым, җан газапларым синең өчен чүп иде!..* А.Гыйләҗев

7) *куч.* Бик җиңел эш; бик вак мәсьәлә. *Бүген Канар атауларына барып гаиләң белән ял итү – чүп ул.* А.Хәсәнов

8) *куч.* Бернинди әһәмияте булмаган, кирәксез кеше, түбән кеше. *Дөнья иде кайгы йорты, Чүп идек без, тирес корты.* Г.Камал. *Ханәфи шикелле өлкән буын кешеләренә чүп итеп кенә карыйлар.* В.Нуруллин

9) *сөйл.* Имезүче ана хайваннарда туманы чолгап алган, аны туклandыру һәм матдәләр алмашы өчен хезмәт

иткән яры (тума дөньяга килгәндә аерылып чыга). *Шулай йөри-юана торгач, сыер да чүбен салды.* Р.Батулла

**2.** *с. мәгъ.* 1) Культуралы үсемлекләргә үсәргә комачаулый торган, аларны чүпли торган. *Басуны чүп үлән баскан*

2) Әһәмиятсез, җитди булмаган, вак. *Анысы гына – чүп хәл.* В.Имамов

3) Түбән, юньсез (кеше тур.). *Нихәтле хезмәт, нихәтле газап – болар бар да фабриканы биләгән чүп адәм өчен.* Г.Нигъмәти

◊ **Чүпкә дә санамау** Бик әһәмиятсез нәрсә дип карау, кирәкмәгән нәрсә дип санау. *Кәримәгә өн кергән иде инде, ул Әнилнең кулыннан кысып тотты да: – Бу Руслан Даулатович... таякны артык бөкми микән? Хатын-кызны чүпкә санамыймы?* З.Хөснияр. **Чүп өстенә чүмәлә** Бер эш өстенә икенчесенең өстәлүен, бер күңелсез хәлгә икенче күңелсез хәлнең кушылуын белдерә. *Чүп өстенә чүмәлә дигән кебек, шул санаулы көннәрне дә башка елны алынганнары шикелле үткәрергә җай юк.* Г.Ибраһимов. *Сугыш дисеңме, ачлык дисеңме, тифы дисеңме – берсе өстенә икенчесе, чүп өстенә чүмәлә булып өелде дә торды.* Г.Толымбай. **Чүп тә тормау** Берәр нәрсәнең башка берәр нәрсә белән чагыштырганда бик әһәмиятсез, бик түбән булуын белдерә. *Ләкин болай эшләү Гөлгенә яхшылыгы каршында чүп тә тормый бит!* Г.Гобәй. **Чүп урынына да тормау** *к.* **чүп тә тормау**

**ЧҮП** II *иярт. к.* **чүп** (*1 мәгъ.*). *Күп тә үтмәде, чүп иткән тавыш ишетелде, һәм Сәхәү карт яңадан сөйләшә башлады.* М.Әмир. *– Җанкисәгем! – дип, чүп итеп үпте.* Б.Рәхмәт

**ЧҮПЕЛДӘТҮ** *ф. сөйл. к.* **чупылдату** (*1 мәгъ.*). *Шаян Ләлә, шуны гына көткән төсле, аның битеннән чүпелдәтеп үбеп тә алды.* Г.Минский

**ЧҮПЕЛДӘ́Ү** *ф.* Иреннәрне җиңелчә чупылдату, чүп-чүп кебегрәк авазлар барлыкка китерү. *Ул авызына нәрсәдер кабып чүпелдәде*

**ЧҮПЕЛДӘШҮ** *ф. урт. юн. к.* **чүпелдәү**. *Светлана, көтеп тә тормыйча, әтешеп кереп, Фатыйманың кочагына сыенды. Алар чүпелдәшеп үбештеләр.* Г.Минский. *Чүпелдәшеп үбешә карлар белән Язгы шаян кояш нурлары.* Б.Рәхмәт

**ЧҮПКӘ́ ЧЫГЫШ** *и.* Оттырган кеше яки оттырган як уеннан төшеп кала бара торган уен. *[Шахматта] чүпкә чыгыштан уйнадылар, ягъни бер партия оттырган кеше уеннан төшеп калды.* И.Гази

**ЧҮПЛӘМ** I *и.* **1.** Тукыганда бизәк төшерү ысулы; шул ысул белән тукып ясалган бизәк. *Киндер станы киендерә, чүпләме күзне сөендерә.* Әйтем. *Кызлар чигү-чүпләм өлгеләрен аннан алалар, аннан өйрәнәләр.* Т.Гыйззәт

**2.** *с. мәгъ. к.* **чүпләмле**. *Менә шул чыбылдыклы караватт янына гына кызыл чүпләм эскәтер япкан кечерәк өстәл куелган.* Ә.Еники. *Биек колгаларга эленгән эре-эре бизәкле шәлъяулыклар, чүпләм сөлгеләр, озын-озын тукымалар җилдә җилферди.* Д.Каюмова

**ЧҮПЛӘМ** II *и. к.* **бишташ**. *Каракаршы бию дисеңме, егетләр кызларга төрттереп такмак әйтешүме, чүпләм уенымы – берсе дә калмый.* А.Вергазов

**ЧҮПЛӘМӘ** I *и.* 1) *к.* **чүпләм** I (*1 мәгъ.*). *Нәфис чүпләмә*

2) *к.* **чүпләмле**. *Соры чүл өстенә, чүпләмә келәм итеп, бүрек-бүрек үләннәр ябылган.* Ш.Галиев

**ЧҮПЛӘМӘ** II *и. бот.* Лаләчәләр семьялыгыннан агулы үсемлек

**ЧҮПЛӘМЛӘ́Ү** *ф.* Тукыганда бизәк төшерү өчен, буй яки аркылы җепләрне билгеле тәртиптә аралаштыру. *Шулай да Саба ягы көмешчеләре (беләзек, йөзек, алка коючылар), итекчеләр, тегүчеләр, чүпләмләп сөлге-тастымал чигү осталары, агачны «чәчәк» итүчеләре белән тирә-юньгә атаклы булган.* И.Нигъмәтуллин. *Асалап сугу ысулы көнкүрештә XIX гасыр урталарына кадәр шактый киң урын алып тора. Гасыр ахырына таба аны чүпләмләп сугу ысулы алыштыра бара.* Казан утлары

**ЧҮПЛӘМЛЕ** *с.* Чүпләмләп сугылган, чүпләмләп тукылган. *Ул яз көне, менә хәзерге шикелле, башын да күтәрмичә, айлар буе киндерләр, чүпләмле сөлгеләр суга, кыш буе намазлыклар, өстәл япкычлары, кульяулыклар чигә, һәммәбезгә дә пирчәткәләр, оекбашлар бәйләп бирә.* Г.Бәширов. *Халык тарала төшкәч, безнең янга Әкълимә апа килде һәм, серле елмаеп, ат муенына чүпләмле сөлге бәйләде.* М.Маликова

**ЧҮПЛӘМЛЕ ТАШ** *и. к.* **чүпләм таш**. *Чүпләмле таш уйнау*

**ЧҮПЛӘМ ТАШ** *и.* к. **бишташ**. *Пәке кадаш та уйнадык, кызларны чүпләм таш та туйдыра башлагач, йөгерешеп, качышып уйнарга тотындык.* Г.Бәширов

**ЧҮПЛӘНДЕРҮ** *ф. сөйл.* Чүпләү, чүп белән тутыру

**ЧҮПЛӘНҮ** I *ф.* 1) *төш. юн. к.* **чүпләү** I. *Тимерче алачыгы артында язгы кар сулары белән болганган, чүпләнгән зур түгәрәк күл җәелеп ята.* А. Шамов

2) Чүп I (*1–4 мәгъ.*) белән каплап алыну, чүп тулу. *Әрҗәсе вак йомычкалар, салам-соламнар белән чүпләнгән машина сигез кызны, Нәби Таҗетдиновны һәм ферма мөдире Гайфулланы алып юлга чыкты.* А.Гыйләҗев. *Ләкин аның әле җир өстенең, ташлар, агач тамырлары, сөяк-санаклар белән чүпләнгән каты җирнең тигез итеп йомшартылуын, эшкәртелүен күргәне булмаган, ахрысы.* Н.Фәттах

**Чүпләнә башлау** Чүпләнергә тотыну. *Идән чүпләнә дә башлады*

**Чүпләнә төшү** Бераз чүпләнү. *Бодай чүпләнә төшкән*

**Чүпләнеп бетү** Тәмам чүпләнү

**ЧҮПЛӘНҮ** II *ф. сөйл.* 1) Эзләнеп, берәр нәрсә чүпләп йөрү, чүпләү II (*2 мәгъ.*). *Бераз утырып торыйм дип җиргә иелсәм, тирәмдә көтүләре белән сыерчыклар чүпләнә.* А.Хәсәнов. *Урамда чүпләнеп йөргән тавыкларга хәтле яныбызга килеп, тыңлап тора башлады.* З.Мәхмүди

2) Аз-азлап кына ашап утыру; ашарашамас утыру. *Табын янында чүпләнеп утыру*

**Чүпләнә башлау** Чүпләнергә тотыну. *Без – туганнан бирле кендегебез береккән өч малай – күшегеп күп-күмгәк булган кулларыбызны бишмәт җиңенә тыгып җылыткандай итәбез дә тагын чүпләнә башлыйбыз.* Сөембикә

**Чүпләнеп тору** Хәзерге вакытта чүпләнү

**ЧҮПЛӘНҮ** III *ф. төш. юн. к.* **чүпләү** III. Вак-төяк эшләр белән шөгыльләнү; бик вак эш башкару. *Төрле җирдән кучергечләр эзләтеп алып чүпләнгән яхшы сөлгеләр, зур-зур ашъяулыклар, салфетлар, өлкән чаршау, күлмәк-ыштан вә чолгау кебек нәрсәләр зур әһәмият белән сугылып, Гөлбану артыннан барачак приданнар рәтенә тезелә бара иде.* Г.Ибраһимов

**ЧҮПЛӘ́Ү** I *ф.* 1) Чүп I (*1 мәгъ.*) белән тутыру, чүп белән каплау. *Бу бабай тагын өйне чүпләгән.* Т.Гыйззәт. *Зарифә хәтерли әле: аларның урамында тупыл агачлары рәт-рәт тезелеп утыра иде. Берзаманны, мамыклары урамны чүпли дип, аларны кисә башладылар.* З.Хөснияр

2) Бер иш нәрсәгә башка, чит нәрсә катнашу; чүп I (*4 мәгъ.*) катнаштыру.

*Койрыкка китә торган башаклар суырган арыш өстенә төшеп чүплиләр.* М.Гали

**ЧҮПЛӘ́Ү** II *ф.* 1) Таралып яткан яки башка төрле азыкны томшык белән эләктереп алып ашау; берәмләп чуку. *Әгәр күгәрчен күченә козгын баш булса, бөтен күгәрченнәр дә, бодай чүпләмичә, үләксә ашый башлый.* Г.Ибраһимов. *Чыпчыклар, песнәкләр, карабүрекләр, шул улакны сырып алып, тау артыннан чыгып килгән кояшка шатланып, берберсе белән үзара шаярышып, чыр-чу килеп җим чүплиләр.* А.Хәсәнов

2) *сөйл.* Берәр нәрсәне бөртекләп, берәмләп җыю, туклану. *Ашап беткәч, егетләр, кайсы учы, кайсы җиңе белән, әйбәтләп авызларын сөрттеләр; Талип итәгенә төшкән валчыкларны да чүпләп капты.* Ә.Еники. *Уйларына чумып җиләк чүпләгән Сәгыйрә сискәнеп китте, куркып-каушап калуына чын күңеленнән елмаеп: «Сине генә инде!» – диде.* Д.Йосыпова. *Тавышка әни йөгереп кергән, агач сәкегә алып салган, кулларымнан пыяла ватыкларын чүпләгән.* Р.Газиз

3) Таралып яткан берәр нәрсәне җыю, җыеп алу. *Кайсы кырын ятып сагыз чәйни, кайсы тәрәшле тарагы белән шытыр-шытыр чәч тарый, ике кыз тәрәзә яктысында баш карашалар, иң кечеләре, мич каршысына утырып, көлдән борчак чүпли.* А.Гыйләҗев. *Алты яшьлек малай авыр крестьян хезмәтендә катнашкан – бакчада бәрәңге чүпләгән.* М.Мәһдиев

4) Нинди дә булса билге, үзлек буенча күпләр арасыннан берәмләп сайлап алу, аерып алу

5) Берәр нәрсәне чит катнашмадан, чит предметтан яки комачаулаучы нәрсәдән арындыру, чистарту максаты белән, ул чит булган нәрсәләрне аерып алу, җыеп алу. *Базда бәрәңге чүпләп утырган бер хатынны күргәч, югалып калмый тагы: – Исәнмесез, саумысыз! – ди.* Б.Ислам

6) *күч.* Эзлекле рәвештә берәм-берәм кулга алу, үтерү һ.б.ш. турында. *Әтине үтерделәр, һәм дошманнар безне берәм-берәм чүпли башлады.* В.Имамов

**Чүпләп бетерү** Беткәнче чүпләү. *Бәрәңгене чүпләп бетердек*

**Чүпли башлау** Чүпләргә тотыну. *Җиргә тезеп салынган эре көнбагыш башларын үрелеп алып чүпли башларга берсенең дә ояты җитмәде.* А.Хәйретдинова

**ЧҮПЛӘ́Ү** III *ф. диал.* Чүпләмләү. *Көнгә бер-ике бизәк чүпләп, зәвыклы матур чигеш хасил була.* Якты юл

**ЧҮПЛӘ́Ү** IV *и. к.* **чүпләм** I. *Аяк астына чыра сыман юка такта-чыбык тыгып күтәреп торалар һәм соса белән аркау җебе үткәрәләр. Шулай сугу ысулы чүпләү дип йөртелә.* К.Насыйри

**ЧҮПЛӘ́Ү** V *ф. диал.* Сугу, ашлык сугу. *Ашлык чүпләү*

**ЧҮПЛЕ** *с.* 1) Чүпләнгән, чүпләнеп беткән, чүп I (*1 мәгъ.*) күп булган. *Барыбер җыелмаган чүпле өй эче күренде.* А.Гыйләҗев. *Безнең өй чүпле икәнен Сизмәсеннәр дошманнар.* Г.Афзал

2) Чүп I (*4 мәгъ.*) баскан, чүп үскән. *Бөтен черки-кигәвене, колорадо коңгызы, чүпле бакчасы, печән өсте мәшәкате, хисапсыз бакча эшләре аша да яратам мин җәйне.* Безнең гәҗит

3) Чүбе I (*5 мәгъ.*) булган, чит нәрсәләр катнашкан. *Ачларга кеше башына егермешәр-утызар кадак чүпле арыш тиде, байлар исә берничәшәр пот алдылар.* М.Галәү. *Председатель «фуражга-нужага» дип, аз-маз чүпле солы белән, печән өстенә, халык бик киселгәндә тотылыр дип, чак кына бодай калдырырга чамалаган икән дә, районнан боерык биреп, үзен нык кына пешерделәр.* А.Гыйләҗев

**ЧҮПЛЕК** *и.* Төрле чүпләрне, яраксыз нәрсәләрне ташлый торган урын, чүп җыя торган урын. *Гөл бакчасын таптап чүплек иттек, И хозур соң тупаслык һәм этлек!* Г.Афзал. *Ул, кала ачкычларын тапшырырга дип, кирмән капкаларын ачкан гына иде, төрек нәүкәрләре, чүплек тапкан карга өере шикелле, диварларга ташландылар.* В.Имамов

◊ **Чүплеккә ташлану** Юкка чыгарылу, юк ителү. *Генетика да, соңрак кибернетика кебек, тыелган, чүплеккә ташланган фән ул чагында.* Р.Юныс. *Хезмәт батырлары, илне Күтәрешкән бер буын, Чүплеккә ташланды.* С.Гәрәева

**ЧҮПЛЕ́К БАШЫ** *и. к.* **чүплек**. *Өен чүплек башыннан авыл уртасына, кеше арасына күчереп утырту белән дөнья түгәлләнәчәк кебек тоела аңа.* М.Хәсәнов. *Кайчандыр өч-дүрт йорттан торып, хуҗалары читкә киткәч, инде алары да сүтелеп, хәзер чүплек башына әйләнеп калган бер тыкрык иде бу.* Г.Әдһәмова

**ЧҮПЛЕЛЕК** *и.* Чүпле булу хәле; чүпле булу дәрәҗәсе. *Чүплелек дәрәҗәсе дә югары түгел.* Кайбыч таңнары

**ЧҮПРӘ** *и.* 1) Әчү процессы китереп чыгара һәм ипи пешерү, кызыл аракы, сыра җитештерү эшендә һ.б.ш. кулланыла торган, гөмбәчекләрдән гыйбарәт масса. *Сөенә-сөенә он иләде, чүпрә җебетте, сөт җылытып камыр куйды.* З.Мәхмүди. *Ак эшләрдән кунагыбыз әнә шул кайнатмалар белән әвәрә килә, аннары, чүпрә белән кабартып, бик тәмле коймаклар пешерә иде.* Н.Гыйматдинова

2) *күч. гади с.* Булдыксыз, юньсез кеше. *– Боламык, чүпрә! – дип ярсыйярсый җикеренгән булды; Коркыт хан, төкерәм мин сиңа, дип котырта диярсең – әйләнеп тә карамады.* В.Имамов. *– Минме чүпрә? – дип, Дамир чәчрәп куйды.* И.Гали

◊ **Чүпрә куерту** Нинди дә булса эшне кирәксезгә сузу, мәсьәләне артык катлауландыру. *Мондый мөнәсәбәтне әзерләү, чүпрә куерту кадәресе дә бар бит әле.* Р.Юныс

**ЧҮПРӘК** *и.* **1.** 1) Тукыма. *Чүпрәктән генә букча тегеп бирү*

2) Тузан сөртү, идән юу, әйбер төрү һ.б.ш. төрле максатлар өчен кулланыла торган тукыма кисәге, калдыкпостык тукыма. *Кулымдагы юеш чүпрәк белән ишек тоткаларын да сөртештергәндәй иттем.* А.Әхмәтгалиева

3) Имчәк баласын төргәндә яки ятырганда астына салына торган тукыма кисәге. *Фәүзия, бала чүпрәкләре арасыннан килеп чыккан ялтыравык нәрсәгә карап, тел шартлатып куйды.* Г.Гыйльманов. *Саҗидә юлда җыйналган бала чүпрәкләрен юып, элеп куйды.* Г.Галиева

4) *сөйл. ирон.* Күлмәк; кием, киемсалым. *Бу нинди чүпрәккә табынучы малай актыгы!* Ф.Яхин. *Кыз дусты янына авышып беткән, хәтта авылда, Гыйләҗетдин кызын театрдан куганнар, базарда чүпрәк сата, дип гайбәт чәчәрләр инде, дигән курку да югалган иде.* Н.Гыйматдинова

5) *күч. сөйл.* Артык йомшак характерлы кеше, җебегән, булдыксыз кеше. *«Аяусызлыгым җитте, ә башка хатын-кызлар алдында эрим дә төшәм. Чүпрәк, чүпрәк! Менә мин кем!» – дип, үзен тирги дә иде.* Х.Камал

**2.** *с. мәгъ.* Тукымадан тегелгән, тукымадан гыйбарәт. *Чүпрәк сумка күтәреп, Зариф кайтып керә.* З.Хәким. *Шулчак йөзе мәетнеке төсле агарынып калган бөкре чүпрәк курчак кебек шәлперәеп төште.* З.Мәхмүди

**ЧҮПРӘКБАШ** *и.* 1) *кимс.* Хатын-кыз. *Әй син, чүпрәкбаш, ир хатынымы син, толмы, әллә кызмы?..* К.Тинчурин. *Берәрсе аның ирләр эше эшләвен күреп: «Әй, чүпрәкбаш!» – дип көлсә, Сәҗидә аптырап калмый: «Синең шикелле тузан арасындагы таш бөртеге булганчы, чүпрәкбаш булу мең өлеш яхшырак», – дип, тегенең авызын каплый.* М.Галәү

2) *тирг.* Аңгыра кеше. *[Гыйльметдин:] Тфү, нигә авызыңны җәйдең, чүпрәкбаш?* Р.Батулла

**ЧҮПРӘКЛӘНҮ** *ф.* 1) Тузып бетү, тузып, эшкә яраксыз хәлгә килү (кәгазъ тур.).

2) *күч. сөйл.* Куркып калу, җебеп төшү; җебегәнгә әйләнү, булдыксызлану. *Тыныч тормышта төпле һәм олпат күренгән агайның чүпрәкләнүе аны аптырашта калдырган иде.* Ф.Хуҗин

**Чүпрәкләнеп бетү** Тәмам чүпрәкләнү. *Алдагы елларда әтидән күк турында мин аңларлык итеп язылган китаплар сорап интектереп бетердем, «Табигать белеме» дәреслегендә космоска караган битләр кат-кат укудан чүпрәкләнеп бетте, әмма галәмгә булган мәхәббәтем сүнмәде...* Х.Ширмән. *Татарча дини китапларны шуның кадәр начар итеп чыгаралар, бер-ике тапкыр укысаң, чүпрәкләнеп бетә.* Безнең гәҗит

**ЧҮПРӘКЛӘТҮ** *ф. йөкл. юн. к.* **чүпрәкләү**. *Мин үземнең хисләремне чүпрәкләтмәм.* Г.Кутуй

**ЧҮПРӘКЛӘҮ** *ф.* 1) Туздыру, таушалдыру

2) *күч. сөйл.* Сафлыгын бетерү, ваклау (хисләр тур.)

**ЧҮПРӘКЛЕК** *и.* 1) Бала чүпрәге итеп кулланырга яраклы материал. *Балага киемлек һәм чүпрәклек кызыл материя бүләк иттеләр.* Ислам – Татарлар һәм мөселманнар

2) *күч. сөйл.* Артык юашлык, җебегәнлек, булдыксызлык. *Бу назы – газаплавы өчен хатыныннан гафу үтенүе, эчүе өчен уңайсызлануы, чүпрәклеге өчен ташлап китүләреннән куркуы иде...* Ә.Гәрәева

**ЧҮПРӘ́КТУРАГЫЧ** *и.* Кәгазь итеп эшкәртелә торган чүпрәкне ваклый, турый торган машина

**ЧҮПРӘ́К-ЧАПРАК** *җый. и.* 1) Төрле кулланылыштагы тукыма әйберләр. *Тәрәзә пәрдәләре, башка чүпрәк-чапрак хәерчелекне бераз каплап тора.* З.Мәхмүди. *Шалаш түбәләрендә сөлгеләр, чүпрәк-чапрак җилферди.* Р.Газиз

2) Чүпрәкләр, чүпрәк кисәкләре, төрле-төрле чүпрәк калдыклары

3) *күч. сөйл.* Тузып беткән киемсалым; гомумән кием-салым. *Ул, чүпрәк-чапрак тулы табак тотып, ваннага кереп бара иде.* Р.Бәшәр. *Польшага, Төркиягә барып, чүпрәк-чапрак алып кайтып, аларны базарда сатып та тора алмас.* И.Нәбиуллина. *Шулай итеп, кичәге укытучы бүген чүпрәк-чапрак сатарга чыгып басты.* Р.Хәбибуллина

**ЧҮПРӘКЧЕ** *и.* 1) Чүпрәк-чапрак җыючы; аламачы. *Авылга чүпрәкче килгән иде, Фатыйма аны күперде очратты.* З.Кадыйрова. *Чөнки Яңа Бистәнең, Акком асты тирәләренең аркаларына капчыклар, кечкенә сандыклар аскан, чүпрәкче һәм вак-төяк сатучы бөкре һәм кәкре янтыклы картларын иртә сәгатьтән үк ташый-ташый да җан чыккан иде.* Т.Нурмөхәммәтов

2) *күч.* Кием-салым белән, чүпрәк белән чамадан тыш мавыгучы хатын-кыз. *Чүпрәкче кызы белән бәйләндем бит.* Р.Батулла

**ЧҮПРӘКЧЕЛЕК** *и.* Чүпрәк-чапрак җыю эше. *Чүпрәкчелек белән шөгыльләнү*

**ЧҮПРӘЛӘ́Ү** *ф.* Чүпрә кушу, чүпрә салу. *Син чүпрәләп күпертеп пешергән икмәкнең, тары беленнәреңнең тәмлелеге үзе ни торган!* Р.Рөстәмова. *Чүпрәләп, күпертеп син пешергән икмәкнең, урта авырлыктагы киледә генә төеп, җылымса суда изеп, юка гына итеп пешергән тары коймакларының тәме үзе ни торган!* Туган як

**ЧҮПРӘЧЕ** *и.* Чүпрә җитештерү эше белән шөгыльләнүче яки чүпрә белән сату итүче кеше. *Чүпрәче Әхмәтҗаннарның үрдәк бөккәннәре пешеп җитмәү, --- итче Вәлинең кызы толчокчы Сабир улына ябышып чыгуы[на] кадәр булган бөтен гайбәтләрне санап чыгалар.* М.Гали

**ЧҮП-ЧАР** *җый. и.* **1.** 1) Чүпләр I (*1 мәгъ.*), вак-төяк яраксыз кисәкләр. *Безнең Космонавтлар урамын һәр дүшәмбедә килеп себерүче бер кечерәк кенә контораның ялкау кызлары коелган яфракларны, чыбык-чабыкларны, башка төр чүп-чарны шул өемгә генә китереп аударалар.* А.Хәсәнов. *Бөтен җирдә тузан, мамык, чүп-чар.* В.Имамов. *– Лом алып киләсе калган, – дип үзалдына сөйләнде ул, берөзлексез кирпеч, таш, пыяла кисәкләре чыгуын абайлап. – Кем уйлаган мулла абзыйның нигезендә шултиклем чүп-чар булыр дип?..* А. Гыймадиев

2) Берәр нәрсәне эшкәрткәндә һ.б.ш. очракларда барлыкка килгән калдык кисәкләр, ташландык нәрсәләр. *[Карп Васильевич:] Урманда утын күп булган өчен генә [ботакларны] яндырмыйлар. Урманда чүп-чар булмаска тиеш.* Г.Әпсәләмов

3) Культуралы үсемлекләр арасындагы чүп үләннәр, чүп. *[Трактор] чүп-чарларның җенен өзеп, тамырын кырып, җир башына өем-өем ташлап китә.* М.Гафури. *Маһибәдәр, кыштырмыштыр килеп, ян бакчага чүп-чар утарга кереп китә.* А.Гыйләҗев

4) Бер иш нәрсәдә булган чүпләр, чит нәрсәләр. *Ярга чүп-чар кага Влтава.* А.Хәлим

5) Тузып, таушалып беткән нәрсә. *Ситдикъ – күзенең бер чите белән генә сәке буена тезелгән әйберләргә карап куйды: «Башка заман булса, синең бу чүп-чарыңны бәдрәф чүпрәгенә тотарлар иде».* Г.Ибраһимов

6) *күч. сөйл.* Әһәмиятсез, файдасыз яки яраксыз нәрсә. *Чүп-чар турында уйлап утырасың, дәрестә игътибарың юк, дип тиргәр.* А.Әхмәтгалиева

7) Мәгънәсез нәрсә, мәгънәсе, әһәмияте булмаган нәрсәләр. *Миемезне, чүп-чар белән тутырып, күп череттең!* Г.Ибраһимов. *Зур хәвефләр, олы эшләре бар, мин тарихтан чүп-чар эзләмим.* К.Сибгатуллин

8) *күч. сөйл.* Абруйсыз, әһәмиятсез яки түбән, эшәке кешеләр. *Син – бөеклек, ә мин – чүп-чар.* А.Җамал

**2.** *с. мәгъ.* Чүп (I) булган, чүптән гыйбарәт, кирәксез. *Чүп-чар сүз сөйләп, оеп утырудан да зур бәхет бармы икән бу дөньяда?!* А.Гыйләҗев. *Халык кычыткан, балтырган, бәрәңге сабаклары, чөгендер яфраклары, алабута кебек чүп-чар үләннәр ашый.* С.Батыршин

**ЧҮПЧАРЛАНУ** *ф.* Чүпләнү, чүп белән тулу

**ЧҮПЧАРЛӘ́У** *ф.* Чүпләү, чүп белән тутыру

**ЧҮПЧАРЛЫ** *с.* Чүпле, чүпләнеп беткән. *Чүп-чарлы бозларның да аскы ягы чиста, зәңгәрсу-саф, агым белән чарланган.* Ш.Галиев. *Мин чүп-чарлы һәм көрпәле түгел, Калмый утырып минем юшкыным.* Ф.Яхин

**ЧҮПЧЕ** *и.* Чүп (I) җыючы, чүп җыю эше белән шөгыльләнүче. *Бламажилары оемаган диганнән, исемә төште:*

*беркөннәрне мин чүпче Әхмәтләргә ашка барган идем, үрдәк бөккәннәре бер дә пешмәгән, авызга алгысыз чи иде, бөтенләй лычкылдап тора.* Г.Камал. *Истанбулда урам чистартучы, ягъни чүпче, аена мең доллар хезмәт хакы ала икән.* Р.Батулла

**ЧҮРӘ** *с. диал.* Кире, тискәре. *Яфракларның чүрә якларын кояшка таба әйләндереп куйганнар.* Ф.Сәйфи-Казанлы

**ЧҮРӘК** *и. диал.* Әче камырдан пешерелгән вак күмәч. *Мәшһүрдер, берзаманда Бәраш исемле бер кеше бар иде. Бөтен куй белән йөз чүрәк ашар иде.* К.Насыйри. *Балалар, сөенечләреннән дала буйлап чаба-чаба, чүрәк пешкәнне көтте.* Казан утлары

**ЧҮРӘКӘ** *и. диал.* 1) Шар. *Чүрәкә сугу*

2) Ярылмаган утын, ярылмаган түмәр

**ЧҮРӘКӘЙ** I *и.* **1.** Үрдәкчәләр семьялыгыннан иң кечкенә үрдәк; *русчасы*: **чирок**. *Чыпчык, чәүкә, күгәрчен, карлыгач, карга, кәккүк, керәшә, сыерчык, акчарлак, карчыга, лачын, сандугач, челән, чомга, чумгалак, чүрәкәй, каз, үрдәк, тавык, чәберчек, чукыр, чуллык, козгын, шоңкар, ябалак, саесскан, тукран, аккош, каракош... – болар барысы да гадәти кош исемнәре.* А.Тимергалин. *Тәрәз яктылыгында чүрәкәй үрдәк очып узганы күренде.* Р.Батулла

**2.** *с. мәгъ. сөйл.* Кечкенә гәүдәле, зур булмаган. *Ул арада ишектән карсак кына буйлы, чүрәкәй генә бер кеше чыгып, француз яулыклы бер карчыкның муенына сарылды.* Ф.Хөсни

**ЧҮРӘКӘЙ** II *и. к.* **кыекбаш**. *Утәмеш Табылдыкны лапта-чүрәкәй уйнарга да өйрәтте.* Р.Батулла. *Без бер төркем малай куй базары янында чүрәкәй уйный идек.* Н.Сәфәров. *Ну, шушы Мортый чүрәкәй калагы ясарга оста да соң.* Г.Лотфи

**ЧҮРӘКӘЙЛЕ** *и. диал. к.* **чүрәкәй** II. *Кайчандыр Кокушкино урамнарында үзе яшендәге крестьян малайлары белән чүрәкәйле, кузналы уйнаган кечкенә Володя ат сакларга куна барып, учак янында әкият тыңлаган.* С.Рафиков. *Авыл урамнары хәтфәдәй яшел чирәм, һәм без, яланаяк, якты көздән караңгы төшкәнче әллә нинди уеннар уйныйбыз: әбәкле, чүрәкәйле, кач-качлы, туп атып тиерешле һ.б.* Татарстан яшьләре

**ЧҮРӘКИ** *и. диал. к.* **чүрәкәй** II. *Чүрәки уены*

**ЧҮРӘЛИ** *рәв. диал.* Тирәли, әйләндереп. *Ызбага чүрәли бау сузып, озын озын тастымаллар сәлендереп җыялар, әрбирләрен күрсәтеп. Өстәл җабулары, тастымаллар алып килә килен.* Милли мәдәни мирасыбыз. Пермь

**ЧҮРӘЧИ** *и. диал. к.* **чүрәкәй** I

**ЧҮРЕ** *и. иск.* 1) Кол кызы, кол кыз. *[Зөбәрҗәт:] Чүре дә итмәсен, сарайда да тотмасын.* Безнең мирас

2) Хезмәтче хатын-кыз, асрау. *Син бит миңа моңарчы чүре итеп карадың, үземнең дә сиңа хезмәтче булудан, служанка булудан котылырга көчем җитмәдә.* М.Хуҗин

**ЧҮТ** *рәв. рус сөйл. к.* **чак**. *Бераз арган, чәй эчеп, чүт кенә хәл алырга теләде.* А.Гыйләҗев. *Әмма авыл советының карарын күргәч, Сәгадәт чүт шартламады.* Г. Әдһәмова

**ЧҮТЕЛДӘ́Ү** *ф. сөйл. к.* **чутылдау**. *Төп тәнкыйть безнең әлеге мәкаләкисәгенә юнәлгән иде (әлеге мәкалә кисәгенә дим, чөнки анда әйтелгән фикерләр, әтәч булып кычкырып караган чеби кебек, чүтелдәүдән ары узмаган иде әле).* М.Госманов. *Аны кискән вакытта, «оныттың, оныттың» дип чүтелди-чүтелди, ике күгәрчен килеп чыга.* Сәхнә

**ЧҮТИ́-МҮТИ** *рәв. гади с. к.* **чак-чак, чүт-чүт**. *Чүти-мүти булса да, Акылыңны йөрт әле.* Б.Рәхмәт

**ЧҮ́Т-ЧҮТ** *рәв. рус сөйл. к.* **чак, чак-чак**

**ЧҮ́-ЧҮ** *ы. к.* **чү**. *[Бикбулат:] Чү-чү, һич тә ачуланырга исәбем юк.* А.Гыйләҗев. *Билгеле инде, Гөлбану да: «Чү-чү, әтисе!.. Саграк кылан... Без бит хәзер икәү...» – дип, чак кына чытлыкланган булыр.* М.Хәсәнов

**ЧЫБАГАЧ** *и. сөйл. к.* **чабагач**. *Ары да лап-лап, бире дә лап-лап, Сөңге саплап, киез каплап, Ука таптап, Бер башыннан бер башына чыктык чак-чак. (Элек чыбагач белән ашлык сугу).* Табышмак

**ЧЫБЫК** *и.* **1.** 1) Тал, виноград, башка кайбер куакларның һәм бик яшь агачның сыгылмалы озын нечкә тармагы. *Каеннар давылда яфраксыз чыбыкларын тирбәтә, ул ялангач булса да сабыр, чөнки аның бөреләре бар, бөреләр язны көтәләр.* Х.Туфан. *Урман буенда корыган чыбыкларны чәчәк бәйләменә охшатып тезүе исенә төште аның.* М.Хуҗин

2) Яшь агачның яки талның җәзалау коралы буларак кулланыла торган нечкә сыгылмалы тармагы. *Чыбыкның сыртымда чыжлаганын көтеп тормадым.* К.Миңлебаев. *Күп чыжлатты ул шаһзадәнең аркасында сыек чыбыкны.* М.Әмирханов

3) Читән тоту һ.б.ш. өчен кулланыла торган яшь тал, нечкә яшь агач. *Өй түренә яшел чирәм тишелеп чыктымы, Гәрәй абзый, берсе озын, берсе кыска тал чыбыгы тотып, койма буендагы эскәмиягә чыгып утыра.* А.Вергазов. *Күбесенең тояклары чабатадай җәелеп, яргаланып беткән. Оча сөякләре, кабыргалары ватык читән чыбыклары сыман тырпаешып тора.* В.Имамов

4) Агачның кечкенә, нечкә ботагы. *Тагы тып-тып бер тавыш килә, вак чыбыкларны чыжылдатып, кем соң ул йөгерә?* А.Алиш. *Куак башлары, зелпе чыбыклары, бишмәт итәгеннән тартып, битне тырнап калалар.* Г.Бәширов

5) Калын җеп яки бау рәвешендәге сыгылмалы металл эшләнмә. *– Кышны биеп уздырыгыз! – ди дә Җил, телеграф баганаларына «утырып», телеграф чыбыкларында кыш җырын җырлый, йорт трубаларын сызгырта.* Һ.Такташ. *Иреннәребез иреннәргә кагылуга, электр чыбыкларының җилдә бәрелешүеннән чыккан очкыннардай, караңгы урамны яктыртып, ут көлтәсе чәчрәр кебек.* Ф.Яруллин

6) Ботаклы сыек нечкә агачтан ясалган печән төяп тарттыру җайланмасы. *Закир аның чыбыкларына ат дугасыннан печән өйгәч, арканны кайтарып салалар; малай кычкырып, шаулап кибәнгә килә, арбасын аудара да тагы кире күбәләргә, Закир янына шаулап чаба.* Г.Ибраһимов

**2.** с. *мәгъ.* Тал яки башка яшь агачның нечкә сыгылмалы ботагыннан үреп ясалган. *Каравыл өе алдын чыбык читән белән үреп алып тырлау ясады, мул итеп укроп чәчте, кыяр-кәбестә утыртты, шешә алып килсәң, кабарга дигәнен үрелеп кенә ала...* А.Гыйләҗев

◊ **Чыбык очы** Бик ерак кардәшлек турында. *Колхозның исәп-хисап эшләрен тиз генә бүтән кешегә тапшырдым да, үзебезгә чыбык очы тиешле Хәерниса апага биштәр капчыгы әзерли торырга кушып (әни үзе булдыра алырлык түгел, ул көннәрдә бик нык өзлегеп ята иде), озын-озак уйлап тормастан, Янтыкка Сәкинә янына киттем.* В.Нуруллин. *Бер чыбык очы тиешле туганнары бар бугай аларның.* А.Гыймадиев

**ЧЫБЫКЛА́У** *ф. сөйл.* 1) Чыбык белән кыйнау, сугу; гомумән кыйнау. *Полицай аның саен атны чыбыклады.* Х.Ка-

малов. *Тау өстендә Бураншаһны бая чыбыклаган малай күренә һәм Башлык каршына очып дигәндәй төшеп тә җитә.* М.Хуҗин. *Иң кыены: көтүдән сарыклар вакытында кайта белми, тыкрык яисә басу артында кунып калуны артыграк күрәләр. Фәния аларны, чыбыклап, үзе алып кайта да абзарга яба.* Р.Низами

2) *күч.* Каты тәнкыйтьләү, тиргәү. *«Жизни» тел төбемне аңлады, борылып, каш астыннан гына карашы белән мине «чыбыклады»...* Н.Гыйматдинова

**Чыбыклап алу** Тиз генә, кыска гына вакыт эчендә чыбыклау

**Чыбыклап килү** Күптәннән бирле, эзлекле рәвештә чыбыклау. *Тормыш аны һаман чыбыклап килде*

**Чыбыклап тору** Әледән-әле, гел, һәрвакыт чыбыклау; хәзер, әле чыбыклау. *Ләкин ниятеннән бер дә чигенергә теләми ул, шуның өстенә тагын этисенә үзенең булганлыгын күрсәтәсе килүе дә эчтән «чыбыклап» тора аны.* Х.Камалов

**Чыбыклый башлау** Чыбыкларга тотыну. *Бераз гына чыбыклый башладыңмы, хәзер авыл советына йөгерәсез.* Т.Гыйззәт

**ЧЫБЫКЛЫ** *с.* 1) Чыбыклары булган. *Хәбирә, ни хикмәт, үз дорфалыгына гафу да үтенеп тормастан, онытылып, дивардагы кечкенә, чыбыклы радиога ябышты.* Ф.Яхин

2) Чыбык белән коралланган; чыбык ярдәмендә башкарылган. *Ул Саматның атка сугарга дип кизәнгән чыбыклы кулын каптырып алырга тиеш иде.* Ә.Дусайлы

**ЧЫБЫКЛЫК** *и.* 1) Чыбыклар (*3–4 мәгъ.*) үсеп утырган урын; таллык. *Вә янә ул вакытта авылларыннан берничә чакрым җирдә Идел яры өстендә бер кечкенә урманлык яки чыбыклык (кустарник дигән шикелле) җирләре бар икән.* К.Насыйри. *Соңрак кешеләр куаклык үскән су буена, чыбыклык тирәсенә күчеп утырганнар.* Зәй таңнары

2) Кисеп өеп куелган кипкән агач чыбыклары. *Ягар өчен, чыбыклыктан ботаклар алып керергә кирәк*

**ЧЫБЫКСЫЗ** *с.* **1.** 1) Чыбыклары булмаган. *Чыбыксыз агач*

2) Чыбык кулланылмаган, чыбыктан тыш эшли торган. *Яурупа халкы чыбыксыз телеграфлар, телефоннар эшләтүне кәшеф кылдылар.* Г.Исхакый. *Әти онытучанрак шул. Менә аның чыбыксыз телефоны икәү. Берсен әни гел кесәсендә тотарга куша, икенчесе эш өстәлендә тора.* М.Хуҗин

**2.** *рәв. мәгъ.* Чыбыктан башка, чыбык кулланмыйча. *Авыл эчендә телефоннары чыбыксыз эшли.* М.Мәһдиев

◊ **Чыбыксыз телефон** Хәбәр, гайбәт һ.б.ш.ның кешедән кешегә бик тиз күчүе, ирешүе. *Бераздан кабул ителгән карар чыбыксыз телефон аша һәр урманчыга барып иреште.* Н.Әхмәдиев. *Авыл җирендә хәбәр бик тиз йөри бит ул: яңа укытучының ат белән килүе чыбыксыз телефоннан кай арада таралып өлгергән дә, сәгать җидедә үк директор ханым мәктәпкә килеп тә җитте, мине кабинетына чакырды.* К.Миңнебаев

**ЧЫБЫКЧА** *и. а.х.* Вегетатив юл белән үрчетү өчен, үсемлекнең тамырыннан, кәүсәсеннән яки яфрагыннан кисеп алынган кисәк. *Әйбәт сортлы виноградны чыбыкчадан үстереп карау теләге дә бар.* Безнең гәҗит. *Җимеш бирәсе агачлар барысы да чыбыкча ялгау юлы белән үстерелгән булырга тиеш.* Кызыл таң

**ЧЫБЫ́К-ЧАБЫК** *җый. и.* Агачтан, куаклардан сынып төшкән яки кисеп алынган нечкә ботаклар. *Ул чыбык-чабыклар өстендә бер уфылдап, бер ыңгырашып ятучы яралыга ымлады.* Х.Камалов // Ягулык буларак кулланылган коры ботак кисәкләре. *Көндезге аш вакытында учак ягарга чыбык-чабык җыябыз.* Ф. Яруллин

**ЧЫБЫЛДЫК** *и.* 1) Йокы урынын, караватны бөтен яктан каплап алу өчен корыла торган пәрдә. *Иң матур чәчәкле чыбылдык белән Фәнияр караватын әйләндереп алдылар.* Ф.Яруллин

2) *сөйл.* Бүлмәне, йокы урынын бүлеп кую яки нәрсәне дә булса каплау өчен пәрдә; чаршау. *Иң түргә, сәке өстенә, ап-ак чыбылдык кордылар.* Г.Бәширов. *Сул яклап бүрәнә стена буена эре чәчәкле ситсы чыбылдык корылган.* Ә.Еники. *Чыбылдык артыннан мышык-мышык елаган тавыш ишетелде.* М.Мәһдиев

**ЧЫБЫЛДЫ́К ЧАРШАУ** *и. к.* **чыбылдык**. *Төнлә, йокларга яткач, чыбылдык чаршау артыннан әнисенең сак пышылдавы ишетелеп калды.* А.Гыйләҗев

**ЧЫБЫРДА́У** *ф. к.* **шыбырдау**. *Шул бәләкәй күлләвекләрдә чыпчыклар чыбырдашып коеналар.* Г.Әпсәләмов. *Имән ботагында кошлар чыбырдаган тавышлар килә.* Х.Ибраһим

**Чыбырдый башлау** Чыбырдарга тотыну. *Яңгыр чыбырдый башлады*

**ЧЫБЫРКЫ** *и.* Хайваннарны куалау өчен юкә, каеш һ.б.ш.дан ишеп ясалган һәм сапка беркетелгән бау. *Ике көтүче, чыбыркы белән җиңелчә генә суккалап, хайваннарны алып килде.* Р.Сәгъди. *Малайлар, чыбыркы сабын күкрәкләренә кысып, таналар артыннан йөгерделәр.* Р.Галиуллин

**ЧЫБЫРКЫЛАП** *рәв.* 1) Чыбыркы белән, чыбыркы ярдәмендә. *Хәзер мин сине каеш чыбыркылап алып төшәм авылга да ышкулыңа илтеп бирәм.* З.Зәйнуллин

2) *күч.* Көчләп, мәҗбүр итеп. *Чыбыркылап эшләтү*

**ЧЫБЫРКЫЛА́У** *ф.* 1) Чыбыркы белән кыйнау, сугу. *Акъялны, һич кызганмыйча, чыбыркылап та, тимерчыбыклар белән дә кудылар.* В.Имамов. *Каршыга йөгереп килүче кызны күргәч, Самат, җырын өзеп, атын чыбыркылап куа башлады.* Г.Галиева

2) *күч.* Нәрсә дә булса эшләргә көчләп мәҗбүр итү. *Курку мине бөтен нәрсәдән дә ныграк чыбыркылады.* Ф.Яруллин. *Шуңа күрә халыкны, көнетөне чыбыркылап, зәмһәрир салкында эшкә куалар.* Ф.Бәйрәмова

3) *күч. сөйл.* Каты, кискен тәнкыйтьләү. *Юкка үзеңне чыбыркылап утырасың.* И.Диндаров. *Узасы эш узган, үзеңне үзең чыбыркылаудан файда юк, туктарга вакыт.* Г.Исхакова

**Чыбыркылап алу** Тиз генә, кыска гына ара чыбыркылау

**Чыбыркылап йөрү** Дәвамлы, озак вакыт чыбыркылау. *Юк шул, хакимият алышынган саен, хыянәтче уллар үз анасын талый, бәгырен өзеп ала, аны сансыз мал урынына чыбыркылап йөртә.* В.Имамов

**Чыбыркылап тору** Әледән-әле, гел, даимән чыбыркылау. *Һәркемне исән-имин котылу хәсрәте чыбыркылап торыр, аркаларына алтын төягәннәре су астына китәр, байлыкның кадере, тормышның рәхәте бетәр.* Ф.Яхин

**ЧЫГАНАК** *и.* 1) Су тибеп чыккан урын, чишмә. *Нибары өч чыганак: Дәү чишмә, Кечкенә чишмә, Урманасты чишмәсе.* В.Нуруллин

2) Берәр күренеш, процесс һ.б.ш.ның башлангычы булып торган нәрсә; нигезе. *Тәрбия чыганагы – гаилә*

3) Нинди дә булса файдалы казылма табыла торган урын. *Тимер рудаларының иң зур чыганакларына Кривой Рог, Курск тирәсендәге чыганаклар*

*керәләр.* Химия. *Яңа нефть чыганаклары эзләргә керештеләр*

4) Нинди дә булса мәгълүматны, хәбәрне беренче булып бирүче кеше; берәр нәрсә турында хәбәр бирүче кеше, оешма. *Берсе гомерен йортына гайбәт ташып уздыра, ә икенчесе үзенең дә гайбәт чыганагы булып китүеннән коты алынып яши.* Р.Рахман

5) Фәнни тикшеренүдә кулланыла торган материал, истәлек, ядкәр. *Әлеге милли хәзинәләребез, тарихи язма чыганакларыбыз, археология ядкәрләребез чал тарихның бик тирән төпкелләреннән башлана.* М.Хәсәнов. *Бу чыганакларның кайберсендә әсәрләрнең үрнәкләре дә китерелә.* М.Хуҗин. *Троицк шәһәре янында казакъ даласында булуын раслый торган беринди дә чыганак юк.* С.Сабиров

**ЧЫГАНАКЧЫЛЫК** *и.* Тарихи язма чыганакларны өйрәнү һәм алардан файдалану ысуллары белән шөгыльләнә торган фәнни дисциплина. *Шул ук вакытта тарих белеменең чын фәннилеккә туры килә торган махсус тармаклары да бар. Мәсәлән, узганны өйрәнер өчен кирәкле мәгълүматларны туплап, аларның ни дәрәҗәдә дөрес хәбәр бирүләрен тикшереп ачыклый торган чыганакчылык (источниковедение) өлеше.* Р.Вәлиев. *Журналның баш мөхәррире Ләбиб Лерон алып барган «түгәрәк өстәл»дә Габдулла Тукайның шәхесен һәм иҗатын өйрәнү, чит илләрдәге, Россиянең башка шәһәрләрендәге мирасын барлау, күптомлыклар һәм «Тукай» энциклопедиясен басмага әзерләү, текстология, әдәби чыганакчылык мәсьәләләре турында сүз барды.* Безнең мирас

**ЧЫГАРМА** *и.* Гомуми кагыйдәдән тайпылу, гадәттәге тәртипкә буйсынмау очрагы. *Ләкин һәр кагыйдәнең чыгармасы була бит, иптәш Таёжников.* В.Нуруллин. *Кагыйдәләрдән чыгарма, ягъни, хәл белешергә килгәндә авырудан хәлен сорарга ярамый торган очраклар.* Ф.Яхин

**ЧЫГАРУ** *ф.* **1.** 1) Нәрсәне дә булса берәр предметның эченнән тышка алу, тышка алып кую. *Мәнә Разия кесәсеннән ниндидер бер язу чыгарып укыды.* А.Алиш. *Фәтхулла куен кесәсеннән карандаш һәм дәфтәр чыгарды, бер битен ертып, ике-өч сүз тырнады.* А.Гыйләҗев

2) Сыеклыкка батырылган берәр нәрсәне кире алу. *Бүрәнәләр, күрәсең, әле яңарак кына судан чыгарылган – аларның кабыклары карайган, ләмгә, комга буялган, арба артларыннан исә пычрак су тамып бара иде.* Н.Фәттах. *Газизне судан тартып чыгаргач та могҗиза дәвам итә.* Г.Гыйльманов

3) Берәр нәрсәне күмелгән, капланган җирдән казып яки тартып алу. *Бал-чыкка типкәли торгач, ике бәрәңге казып чыгарды бу.* Р.Зарипов. *Машинаны кардан чыгарырга ярдәмчеләр килеп җиткән.* Идел

4) Каян да булса берәр нәрсәне күтәреп алып чыгу, күчерү. *Өченче көнне әни миңа әти йоклаганнан соң ашарга чыгарды.* Г.Бәширов. *Кызыл галан бәрәңге эре, яңа гына баздан чыгарылган, шуңа күрә халык, кем әйтмешли, ябырылып алды.* Р.Кәрами

5) Кемне дә булса берәр нәрсәнең эченнән, чикләреннән читкә җибәрү, юнәлтү. *[Дәүли:] Шуңа күрә сине авылдан чыгармаска куштылар.* Т.Гыйззәт. *Кемне-кемне, әмма Рәсүлне шәһәрдән чыгармаска, диделәр.* Ф.Яхин

6) Берәр нәрсә аша тышка үткәрү, тышка сузу, тышка кую. *Кыз аягын тишектән чыгара да иң элгәр братның йөзенә төкерә, аннары бүреген, умырып алып, теге тишеккә ата.* Ф.Садриев. *Бу тимер өеме безне монда китереп бикләде дә, хәзер тычканны тишектән чыгарып, үзе тишек янына килеп баскан мәче шикелле, күзләрен елтыратып көтеп утыра.* Ялкын

7) Тышка салындыру, тыштан күренерлек итеп калдыру (чалбар балагы, күлмәк һ.б.ш.ны). *Әбүзәр кинәт күзләрен ачты: биленә бизәкле киң каеш буып йөри торган шәһәр малае нишләптер күлмәген тышка чыгарып кигән түгелме?* А.Тимергалин. *Фаягөлнең башына кыңгыр салган ак береткасы, искерәк булса да, гәүдәсенең сылулыгын күрсәтеп торган кыска пәлтәсе, монда килгәч юнәткән кара резин итеге, пәлтәсе өстеннән чыгарып салган озын ике толымы – барысы да кояш нурында коена, кызның күзләрендә бар сафлыгы белән аяз күкнең зәңгәрлеге чагыла.* А.Әхмәтгалиева

8) Пар, төтен һ.б.ш.ны бүлеп чыгару, бөркетү; читкә җибәрү, эчтән тышка өрү яки өрдерү. *Нәкъ шул вакытта кече яктан, парларын чыгарып кайнап торган самавыр күтәреп, Зөлкамал килеп чыкты.* Г.Галиева. *Зәңгәр төтеннәр чыгарып, автобус кузгалып та китте.* К.Кәримов

9) Бәреп, төртеп, сугып һ.б.ш. юллар белән нәрсәне дә булса үз урыныннан төшерү, кире алу. *Былтырның утын кисүе, Шүрәле белән сөйләшүе, чөйне чыгарыр өчен балтасын ары-бире селтәве төгәл, ачык буяулар белән бик нөхтә эшләнгән.* Т.Әйди. *Мәнә ул соңгы кадакны суырып чыгарды һәм тартманы ачты.* Кызыл таң

10) Нәрсәне дә булса урнашкан урыныннан кая да булса күчерү, икенче урынга урнаштыру. *Ниса казларны агач келәткә тәрәп салынган кирпеч сарайга чыгарып урнаштырды.* М.Хуҗин. *Чанага тагы ике юл капчыгы чыгарып урнаштырдылар.* Р.Мөхәммәдиев

11) Берәр урыннан тышка алып чыгу; ташлау. *Велосипедны, аяк арасында уралмасын дип, чоланга ук чыгарып ташладылар.* А.Гыйләҗев. *Һәм ул Михаилны култыклап дигәндәй ярга чыгарды да кире күтәрелде.* М.Кәбиров

12) Кемне яки нәрсәне дә булса берәр урынга кадәр җиткерү, китерү. *Колун балта белән Нил абый чыбыкларны сындыра, мин, көрткә бата-бата, юлга чыгарам.* И.Юзеев. *Ул безне өйгә илтеп куяр да, аннары сине олы юлга чыгарып, берәрсенә утыртып җибәрер.* М.Маликова

13) Куллардан ычкындыру, тотып тормый башлау. *Һади йомылып артка ташланды, хыянәтче иптәшләре аны бождрадан чыгармадылар.* А.Гыйләҗев. *Таһир аны кочагыннан чыгармады.* А.Хәсәнов

14) Берәр нәрсә аша күчерү, кичәргә ярдәм итү (елга, күпер һ.б.ш. аша). *Ниһаять, киң елга буена килеп чыктылар. Теге якка чыгарып куючы эзләп карадылар.* М.Хәсәнов. *Ә тегеләр гаскәрне елга аша чыгардылар.* М.Хәбибуллин

15) Ярышларда үзеннән алга уздыру. *[Зөлфия:] Вымпелны үзе дә алмый, бүтән савымчыларны да алга чыгармый.* Ә.Хәкимов

16) Кемнедер эш урыныннан, вазифасыннан алу, бушату, азат итү. *Әнине эштән чыгарганнар.* Ф.Яруллин

17) Ирекккә җибәрү, азат итү (мәсәлән, тоткынлыктан). *Өч айдан соң профессорны, шәһәрдән беркая да китмәскә дип кулыннан язу алып, төрмәдән чыгардылар.* Г.Әпсәләмов. *Гөлбануны да камерага озаттылар. Атна да үтмәде, Гөлбануны чыгардылар.* М.Хәсәнов

18) Берәр кешене яшәп торган урынын, квартирын ташлап, калдырып китәргә мәҗбүр итү, куу. *XVIII гасыр-*

*ның урталарыннан булса кирәк, япон дәүләте үзен башка бөтен халыклар, илчелекләр өчен ябык дип игълан итә, барлык чит кешеләрне илдән чыгара*. Б.Рәхимова. *Никахлы ир белән хатын булсалар да, загста язылышмагач, Рәсимәне квартирдан чыгарганнар*. Туган як

19) Берәр нәрсәне ераккарак, читкәрәк ташу, илтү. *Авылда калып та, аяк өсте тора алганнары белән кара көздән бирле станциягә ашлык чыгаралар иде*. Л.Хәмидуллин. *Ел буе җыелган тиресне чыгарып, бакча-басу буйларына ташып куйды*. Г.Гыйльманов

20) *махс.* Товарларны башка дәүләткә җибәрү, экспортка озату. *Фермерлар үзләре җитештергән уңышны чит илгә дә чыгаралар*

21) *сөйл.* Товар сатылуга килү, сатылуга куелу. *[Хәйри:] Иртәгә үк, Алла боерса, кибетеңне ачарсың да яшергән товарларны чыгарып сату итә башларсың...* Г.Ибраһимов

22) Нинди дә булса эчке халәтне йөздә, чырайда чагылдыру, сиздерү, күрсәтү. *Үзен ничек кенә нык тотарга, ихтыярлы итеп күрсәтергә, бирешмәскә, җебеп төшмәскә тырышмасын, безне капчыкта саклап булмаган кебек, эчтәгене йөзгә чыгармый калу мөмкин түгелдер, күрәсең*. С.Поварисов. *Ул, йөзенә җитди кыяфәт чыгарып, дәрәҗәсен югалтмыйча җавап кайтарырга тырышты*. В.Имамов

23) Нинди дә булса тавыш, авазлар барлыкка китерү. *Хәтта алтын каурыйлы кошларның мең төрле авазлар чыгарып сайрашуын ишеткәндәй булды*. М.Хәсәнов. *Пароход китеп, әллә ни вакыткача дулкыннар ярга бәреләбәрелә, кайта-кайта, төрле тавышлар чыгарып чупырдашалар*. А.Гыйләҗев

24) Аңкыту, тарату (ис). *Боларның аслары ягулы, өсләреннән бу чыгып тора, берничәсе ит куырганга охшаш чыжылдый, май, көек исе чыгара*. Г.Ибраһимов. *Сөмбел, тирә-якка тәмле ис чыгарып, бакчада коймак пешерергә тотынды*. З.Кадыйрова

25) Тамызу, агызу, түгү (күз яшьләре). *Габделәхәт, укыйсы бик килсә дә, фәкыйрьлекләреннән укый алмый калуын күзләреннән яшьләр чыгарып белгерткән иде*. Г.Исхакый. *Идарәгә әби барды, Күзләреннән яшь чыгарды*. Г.Афзал

26) Нәрсәнең дә булса бер өлешен бирү, бүлеп бирү. *Дамир өйдә калды, аның атларына да солыдан әз-мәз өлеш чыгардылар*. А.Гыйләҗев. *Тәскирә дә иртәле-кичле яңа сауган сөттән өлеш чыгара торган булды, бәрәңгесе, икмәктозы да уртак иде*. Г.Гыйльманов

27) Табу, җир астыннан казып алу (файдалы казылмаларны). *Бер ветеран истәлегенә Урман ачып, чуен юллар салды. Җир астыннан күмер чыгарды*. Р.Фәйзуллин. *Ул менә гомере буена таш чыгарды, тирә-юньдәге авылларда аның ташы тезелмәгән мунча да юктыр*. Ф.Җамалетдинова

28) Берәр нәрсә барлыкка китерү, булдыру, пәйда итү. *Анда безнең прапорлар-җилбәзәкләр белән мөселман байлары, муллалар, иман укып, тәкбир әйтеп, яшьләрне, мөгаллимнәрне суеп, үтереп, ерактагы Даутов планынча безгә каршы «борай фронты» дигән бер бәла чыгарып, халыкны әвәрә кылганнар икән!* Г.Ибраһимов

29) *сөйл.* Уйлап табу, нәрсәдер эшләү юлын ачу. *Кешеләр уйлап чыгарган бәйрәм түгел ич бу, табигать биргән бәйрәм...* А.Гыйләҗев. *Әлеге шул берләштерү мәсьәләсен дә, миннән котылу өчен, ул уйлап чыгаргандыр дип шикләнгән идем*. В.Нуруллин

30) Нинди дә булса әдәби яки музыкаль әсәр иҗат итү. *Кушылып җырлыйм җилләргә, җил чыгарган көйләргә*. Аманулла. *Кичке уенда Шәһри җыр чыгарды*. Ф.Яхин

31) Бастыру, нәшер итү. *Буш вакытларда газета чыгарабыз*. Г.Кутуй. *Алар күпме шигырь язды, Күпме китап чыгарды*. К.Булатова. *Ләбибә апа, матурым, байтак кына яшь авторларның беренче китапларын чыгаргандыр*. А.Хәсәнов

32) Бастырып тарату, әйләнешкә кертү. *Штраф түләргә җиңелрәк булсын өчен, Рәсәй 500 һәм 1000 сумлык яңа акчалар чыгарды*. К.Кәримов. *Русиядән калмыйча, Татарстан да үз ваучерларын чыгарды*. Безнең гәҗит

33) Эшләү, салу, төзү (мичне). *Авылда Галләм бабайны мич чыгарырга чакыралар*. Н.Фәттах. *Коесын казыйбыз, мич чыгарабыз һәм башка шундый күз күргән эшләр*. А.Гыйләҗев

34) Йомырка басып утырып, чебиләр барлыкка китерү (кошлар турында). *Урсал тауларында һәр яз саен Каракошлар бала чыгара*. Н.Әхмәдиев. *Кетәклектәге ояда кыртлый тавык, утырып, чебиләр чыгарган*. Ф.Яхин

35) Чәйне кайнаган суда пешереп, төсен һәм тәмен тиешле дәрәҗәгә җиткерү. *Чәй дигәннән, Рангазар чишмәсенең суы чәй чыгармый икән*. Р.Гаязетдин

36) Күңелдән, хәтердән һ.б.ш. алып ташлау, оныту. *Шул Гайни йөзе караны бер дә күңелдән чыгарып булмый, үзе болай бик матур да төсле түгел*. Г.Камал. *Синең хатыңны укыгач, мин башка эшләрне баштан чыгардым*. Ә.Еники

37) Нинди дә булса хәлдән, халәттән котылырга ярдәм итү, икенче бер хәлгә, халәткә күчерү. *Сез аны бер ай депрессиядән чыгара алмадыгыз, башта өч көн комада ятты*. З.Кадыйрова. *Төшенкелектән чыгарга кем ярдәм итә*? Ялкын

38) Фикер йөртү, тикшерү һ.б.ш. нигезендә нинди дә булса нәтиҗәгә, карарга килү. *Ә менә Фатыйма карчык бу вакыйгадан олы мәгънә чыгарды*. Г.Гыйльманов. *Рәис Илдарович мондый кискен фикер чыгару ягында түгел идеме, әллә җавап белән канәгатьлек таптымы, – аларын ук белдереп тормады*. Ф.Яхин

39) Тикшерү, хәл итү өчен тәкъдим итү, кую. *Арытаба көн тәртибенә чыгарылган мәсьәләләр буенча эзлекле фикер алышу булды*. Кызыл таң

40) Уйлап, исәпләп, тиешле җавабын табу (мәсьәлә чишкәндә). *Бу саннарны гомуми билгеләмә итеп алдым да, миллион ярымлы Казан халкына бәйле чагыштырма тигезләмә төзеп, җавабын чыгардым*. Ф.Яхин

41) Нинди булса сүз, идея, вакыйга һ.б.ш. турында билгеле караш, билгеле позиция, фикер тудыру. *Шуңарга Тимерҗанның һәр фокусын ялганга чыгарырга тырышадыр*. Ф.Яруллин. *Инде башларына европа эшләпәсен киюне, ак яка өстеннән төсле бант тагуны, кәчтүмнән йөрүне дә дөрескә чыгарганнар, җитмәсә үзләре дә шулай киенеп алганнар*. Ф.Яхин

42) *сөйл.* Берәр зат, әйбер яки күренеш хакында нинди дә булса хәбәр тарату. *Һәм, чыннан да, әгәр икесе дә йөзәр сум тамызган булмасалар, чынлап та кеше арасына исемнәрен чыгарачак идем, ярый әле биреп котылдылар*. Г.Камал. *Юк-бар кеше турында гайбәт чыгара алмыйлар*. Р.Батулла

43) Киң халык массаларына игълан итеп, гамәлгә кертү (норматив актларны). *Бу якларны үзләштерү кирәк, Патша шундый указ чыгара*. Н.Әхмәдиев. *Идарә утырышында карар чыгардык*. А.Гыйләҗев

44) Рәсми карар нигезендә әзерләп гамәлгә кертү. *Әлеге зур вакыйга хөрмәтенә «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» Россиянең дәүләт медале чыгарылды*. Шәһри Казан

45) Кемнән дә булса Коръәнне, нинди дә булса аерым сүрәне тулысынча укыту. *[Зөләйха:] Менә Коръән чыгарыйм дигән идем. Г.Исхакый*

46) *күч.* Нинди дә булса сер булган яки яшереп сакланган уй-фикерләрне, хисләрне сөйләү, кешегә белдерү. *Ә Закир аңа ышанып, бөтен эчке серләрен чыгарып салган.* Акчарлак

**2.** *ярд. ф. мәгъ.* 1) Ниндидер эшнең билгеле бер чиккә җиткәнче үтәлүен белдерә. *Суны кайнатып чыгару*

2) Нинди дә булса эшнең тулысынча үтәлүен белдерә. *Өйне җыештырып чыгару*

◊ **Чыгар да сал** *гади с.* Бернәрсәгә карамастан нәрсәнедер хәзер үк бирүне яки әзер хәлдә китерүне таләп итү турында. **Чыгарып алу** *этн. к.* **ябыштырып алу** (**чыгару**). *[Сибгать:] «Әгәр шул төнне чыгарып алмасам, иртәгесен аны Караталга бирәләр иде», – диде.* А.Шамов. **Чыгарып сал** *к.* **чыгар да сал**. *Барысын да үзең чыгарып сал, юкса...* В.Имамов. *Бер баштан икенче башка йөргән хәрби патруль үзенчә акча эшли: сәдәфең төймәләнмәгән икән, акчаңны чыгарып сал.* З.Мәхмүди

**Чыгара бару** Эзлекле рәвештә, бербер артлы чыгару. *Лена минем күңелемнән, азлап-азлап, Ларисаны кысрыклап чыгара барган...* А.Гыйләҗев

**Чыгара башлау** Чыгарырга тотыну. *Хафиз карт, йөк өстенә менеп утырып, бисмилласын әйтеп, брезент сумкасындагы ризыкларны чыгара башлады.* В.Нуруллин

**Чыгара тору** Ниндидер эш, процесс башланганчы яки шуның барышында чыгару. *Тол хатын Гөлйөзем белән Шәвәли карт бу авыр язмышны озаклап, кабатлап сөйләгәндә, Мәрхәбә һаман күзеннән яшен сөртә-сөртә утырды; шуның белән бергә төенчеген бөтенләй чишеп, аннан бүләкләрен чыгара торды.* Г.Ибраһимов

**Чыгара төшү** Берникадәр, бераз чыгару. *Чалбар балагын итектән чыгара төшү*

**Чыгара язу** Чак чыгармый калу. *Мәүләви беренче күрүендә, Харисовның күзе һәм колагы белән булашып, шул турыда әкият чыгара язган иде.* Г.Толымбай

**Чыгарып алу** Аз гына, кыска гына вакыт чыгару. *Бармаклары белән өстәлгә сугып, барабандагы кебек ниндидер тавыш чыгарып алды.* З.Зәйнуллин

**Чыгарып җибәрү** Озакка сузмыйча чыгару. *Мин кыз баланы бу хәлендә урамга чыгарып җибәрә алмыйм.* А.Гыйләҗев. *Стройдагы барча солдатларны чик буйлап йөрергә чыгарып җибәрделәр.* М.Маликова

**Чыгарып килү** Күптәннән һәм даими чыгару, чыгаруны дәвам итү. *Авыр сугыш елларында, СССРдагы әдәби журналлар барчасы тукталып торганда да, Татарстан Язучылар берлеге чыгарып килгән «Совет әдәбияты» («Казан утлары») журналы белән ничек горурланмыйсың?* А.Тимергалин

**Чыгарып кую** Кинәт, бер тапкыр чыгару. *Рюмка, нечкә зыңгылдап, матур тавыш чыгарып куйды.* З.Зәйнуллин

**Чыгарып салу** Кисәк кенә, шунда ук чыгару. *Юкка булган икән: чапкын килә-килешкә ук, иряреннән төшеп тормыйча да яңалык чыгарып салды.* В.Имамов

**Чыгарып тору** Даими чыгару; хәзер, әле чыгару. *Ис чыгарып тору*

**Чыгарып яту** *сөйл. к.* **чыгарып тору**. *Алар аны җыеп алалар икән дә, акрын гына аска үткәреп, чишмәләргә, елгаларга өлеш чыгарып яталар икән.* А.Гыйләҗев

**ЧЫГАРЫЛМА** *и.* **1.** 1) *иск. к.* **чыгарма**. *Чыгарылма бары тик аның сабыйлар, чын чирле һәм карт кешеләргә карата мөгамәләсенә генә кагыла ала иде.* Р.Гаязетдин

2) *мат.* Дифференциаль исәпләүләрдә функциянең үзгәреш тизлеген характерлый торган төп төшенчәсе; *русчасы:* **производная**

**2.** *с. мәгъ. махс.* Нәрсәдән дә булса китереп чыгарылган, барлыкка китерелгән. *Анда, аның чыгарылма зурлыгы буларак, үзенең керем һәм чыгым вәкаләтләренә ия булган Татарстан Республикасы бюджеты хасил була.* Ватаным Татарстан

**ЧЫГАРЫЛУ** *ф. төш. юк. к.* **чыгару**. *[Әпрәй:] Аннан, товарищ политотделенҗә, үзең беләсең, (күңелсезләнә) теге бригададан чыгарылганнан соң, үкертеп эшләп тә йөрим инде.* А.Алиш. *Мондый матурлык турында чыгарылган көйләр, моңнар да мәдәниятнең иң матур җәүһәрләреннән торалар.* Г.Кутуй. *Кичә басуларга билгеләнгән күләмдә ашлама чыгарылды.* М.Вәлиев

**Чыгарыла башлау** Чыгарылырга тотыну. *Ашлар чыгарыла башлады.* Г.Ибраһимов. *Татар телендә гәзит чыгарыла башлый, татар мәдәният йортында концертлар һәм спектакльләр куела.* Т.Әйди

**Чыгарылып тору** Даими, гел чыгарылу; хәзерге вакытта чыгарылу. *Бу күзәнәкләр кан ясаучы органда – сөякнең кызыл җелегендә ясалып торалар, талакта тупланалар һәм даими рәвештә, кирәк кадәрле микъдарда, канга чыгарылып торалар.* Ф.Бәйрәмова

**ЧЫГАРЫЛЫШ** *и.* 1) Уку йортын бер үк вакытта тәмамлаган укучыларның чираттагы төркеме. *Аны тәмамлаган беренче чыгарылыш студентлары, мәсәлән, Мәскәүдә укыганнардан кимхур түгел!* Ю.Сафиуллин

2) Заемның аерым бер вакытта кулланууга чыгарылган партиясе

3) Газетаның берәр истәлекле саны яки әдәби, фәнни әсәрнең шундый тиражы. *Мин Украинада сәяхәт кылып йөргән көннәрдә, «Комсомольская правда» шул ил өчен махсус чыгарылышында миллиардер Ринат Әхмәтовның арзан бәягә зур ширкәтләрнең акцияләрен сатып алуын тәнкыйтьләп чыкты.* Д.Гыйсметдин

4) Нинди дә булса җайланма, машинаның яңартылган, камилләштереп җитештерелгән моделе. *«Жигули»ның соңгы чыгарылышы!* А.Гыйләҗев. *Айфонның яңа чыгарылышы*

5) Даими радио яисә телевидение тапшыруының эфирга чыккан чираттагы кисәге. *«Пусть говорят» тапшыруы чыгарылышының икесенең берсе шушы темага багышлана.* Шәһри Казан. *Тапшыру чыгарылышларына темаларны сайлаганда, менә шушы ике юнәлеш геройларын күрсәтергә тырышабыз.* Әгерҗе хәбәрләре

**ЧЫГТАЙ** *и. тар.* Баштан XIII гасыр ахырыннан алып XIV гасыр ахырына кадәр Мавәраэннәһер территориясендәге күчмә кабиләләр вәкиле, соңрак (XIX гасыр ахырына кадәр) хәзерге үзбәкләр белән уйгурларны берләштергән халыкның вәкиле. *Алтын Урда җирлегендә туып, Идел йортта гаять киң таралган Рабгузый китабын да әдип, мәсәлән, чыгтай ядкәре дип кенә карый.* Х.Миңнегулов. *Аның аркылы без Суфи Аллаһияр, Ясәви шикелле чын суфи шагыйрьләргә генә түгел, бәлки турыдан-туры чыгтай классикларына, Нәваиларга тоташабыз.* Т.Әйди

**ЧЫГТАЙЧА** *рәв.* **1.** 1) XV–XVI гасырларда формалашкан, Урта Азия территориясендә гамәлдә йөргән язма әдәби төрки телдә, чыгтай телендә

2) Чыгтайлар рәвешенчә, шулар кебек. *Чыгтайча киенеп йөрү*

**2.** *с. мәгъ.* Чыгтай телендә булган. *Күп сүзләр татарча, госманлыча һәм чыгтайча формада кара-катыш йөртелә.* Г.Рәхим. *Шул рәвешчә, әсәрнең мөндәриҗәсендә булсын, телендә булсын, беркадәр аермалар бар. Безнең «Мәликә китабы» яки башка бер чыгтайча вариантыннан күчерелгән, яки татар укучысының үз тарафыннан үзгәртелгән һәм кыскартылган булырга кирәк.* Н.Исмәгыйлов

**ЧЫГУ** *ф.* **1.** 1) Эчтән тышка табан хәрәкәт итү // Нинди дә булса корылманы, бинаны калдыру, аның эченнән тышкы ягына хәрәкәт итү, китү. *Әни ап-ак кулъяулыгы белән минем тузанга, канга буялган борын тирәләрен рәтләп торганда, әти кибеттән чыкты, без сәфәребезне дәвам иттек.* А.Гыйләҗев

2) Тиешле эзеннән, кысасыннан, юлыннан, юнәлешеннән ычкыну, төшү, читкә китү, читкә күчү. *Инде соңгысы менеп җитте дигәндә, беренче вагон тимерьюлдан чыкты, һәм соңгы вагон авышлык авызында эленеп калды.* Ф.Зариф. *Ул ат юлыннан чыкты, тауның биек чокаймәсенә басып, карашын ерак-еракларга юнәлтте.* А.Хәлим

3) Ниндидер таррак яки ябулы урыннан ачык, киңрәк урынга килү, кая да булса килеп күренү. *Вакытында йоклый, вакытында һавага чыга, уйный, шуңа күрә алма кебек кызарып, матур булып үсә икән.* А.Алиш. *Мирвәли урамга чыкты...* А.Гыйләҗев. *Хәят эшкә киткәч, Миңзаһит бакчага чыкты.* Ф.Садриев

4) Тигез бер рәт булып тезелгән кешеләр яки предметлар арасыннан бер читкәрәк күчү, читтәнрәк позиция алу. *Шеренгадан бер адәм алга чыгу*

5) Йөзе. Алгы ягы белән кайсы якка булса да караган, юнәлгән булу. *Бүлмәнең тәрәзәсе терраска, аннан бакчага чыга икән.* Г.Ибраһимов

6) Дәвалану, җәза үтү һ.б.ш. урыннан тиешле вакытта китү. *Төрмәдән чыгу. Хастаханәдән чыгу*

7) Берәр максат белән кая да булса юнәлү, бару, китү. *Шулай көннәрнең берендә без разведкага чыгып киттек.* Г.Әпсәләмов. *Көннәрдән бер көнне Бачман хан ауга чыкты.* Г.Гыйльманов

8) Берәр нәрсә аша үтү, узу; нәрсәне дә булса кичү. *Сәлим хан берәүгә дә күтәрелеп карамады, күпердән чыгуга, атын Болгар кала тарафына борды.* М.Хәбибуллин

9) Ярышта алга узу, башкаларны узып китү. *Алга чыга алмадым, узып киттеләр, узып!* А.Гыйләҗев. *Иң беренче булып алга чыккан кыздан ярты кул чамасы артка калгач кына байталның касыкларын искә төшерде ул.* В.Имамов

10) Нәрсәгә дә булса җитү, берәр нәрсәгә таба илтү, шуңа килеп төртелү. *Кыр капкасы дип йөртелгән җирдә – авыл башында – юл икегә аерыла: уңдагысы – боргаланып-боргаланып Акташ тауга таба менә, сулга каерылсаң, Күҗемгә – ар авылларына барып чыгасың.* Р.Мулланурова

11) Билгеле үсеш чорына керү, киләсе яшькә күчү. *Алар белән бергә Верещагин, хәвеф-хәтәргә очрамыйча, яңадан күлне йөзеп чыкты.* Г.Әпсәләмов. *Шул көенчә ул үсеп җитте, ир булды, Торна килеш илленең теге ягына чыкты.* З.Зәйнуллин. *Җитмешнең теге ягына чыккач, ялгыз гына әллә ни майтарып булмый икән шул.* В.Имамов

12) Берәр предметның эченнән шуып, очып һ.б.ш. рәвешле тышка күчү. *Ачык конвертлы хат, китап эченнән чыгып, кыйгачлап очып барды да карават астына төшеп китте.* Р.Вәлиев

13) Нинди дә булса предмет эчендә булган нәрсә үз урыныннан кубу, алыну, читкә китү, бушап, суырылып төшү. *Ләкин, ярыктагы чөй чыгып киткән дә, бүрәнә ярылмаган.* Н.Фәттах. *Кадак каккан урыннан чыккан*

14) Каймыгу, үз урыныннан кузгалу, таю. *Бухаровның кулы чыккан, табиблар аңа төзәлергә бер атна вакыт бирә.* Безнең гәҗит. *Баш бармак янындагы сөяк чыкмасын өчен, 4 аш кашыгы ваклап киптерелгән чәчәкне шешәдәге 1 стакан алма серкәсенә салалар, 50 мл йод өстиләр, яхшылап болгатып, 14 көн торалар, аннары аяк табаннарына һәм сөяк турысына иртән һәм кичен ышкыйлар.* Мәдәни җомга. *Бәхетемә, аяк-кулларым сау, ике кабыргам сынган, буын чыккан, башым каты яраланган, колак тиресе ярылган.* Безнең гәҗит

15) Берәр нәрсәнең эченнән тышка тибү, бөркү, бүлену. *Йомык күздән дә яшь чыга.* Әйтем. *Монысы инде чамадан тыш иде: Ханзафаровның хәтере калды, йөзенә бөрчек-бөрчек тир чыкты.* Г.Әпсәләмов

16) Үзенең чикләренә сыймыйча читкә ташу. *Шушы куәтле яңгыргамы, елга ярларыннан чыкты, болыннарга җәелде.* М.Хәбибуллин

17) Берәр нәрсәнең өстендә күренү, барлыкка килү. *Менә шунда Мөслимә сынатты: агарды да күгәрде, битенә тимгел-тимгел кызыл таплар чыкты.* Н.Әхмәдиев. *Укыган арада Даниярның тыны кысылып, йөзенә кызгылт тимгелләр чыкты.* М.Хәсәнов

18) Йөздә берәр хис, кичереш билгеләре чагылу, күренү. *Зәйнетдинов язган диктантны карап чыкканнан соң, ул әлеге хаталар журналына күз төшерде: йөзгә шатлык чыкты.* Г.Кутуй. *Гөлгыйзар кәефсез иде. Төсенә әллә нинди кайгы чыккан иде.* Г.Исхакый

19) Нәрсәнеңдер астыннан күренеп тору, тышка, өскә калкып, күтәрелеп яки тырпаеп тору. *Командирның пилоткасы астыннан озын коңгырт чәчләре чыгып тора иде.* Г.Әпсәләмов

20) Организмда берәр әгъза яки башка нәрсә үсү, барлыкка килү. *Керәсе иде, бер генә күзе белән булса да күрәсе, алсу яңаклы, инде ике теше чыккан улын кулына алып сөясе, үчтеки итәрәсе килә иде.* Н.Әхмәдиев. *Мыек чыккан чорны көтә-көтә Әрәм булды минем күпме көн...* Х.Туфан

21) Шыту, үсеп җир өстенә калку, туфрак астыннан калкып күренү (үсемлекләр тур.). *Сыза кипшергән, читчитләренә котырынып үлән калыккан, уентык-уентык булып, кузгалак тишелеп чыккан.* А.Гыйләҗев

22) Тәндә берәр төрле шешкән урын, чуан һ.б.ш. барлыкка килү. *Әнә Суташтан бер кызны китереп салдылар бүген, бит уртасына чуан чыккан, тула да тишелә, тула да тишелеп ага икән.* М.Маликова. *Атның колак төбенә ниндидер шеш чыккан була.* Кызыл таң

23) Офык өстенә күтәрелү. *Ул арада инде кояш та чыкты, көн булды.* Г.Бәширов. *Каладан утарга таба кузгалган көнне күк йөзе чалт аяз, мөлдерәп кояш чыккан, шәһәр уянган иде инде.* М.Хәбибуллин. *Урман артыннан, мәйданга көрәшергә чыга торган батыр егет кебек, тулып килә торган ай чыкты.* Г.Исхакый // Караңгы төшү белән күренә башлау. *Кайтып җиткәнемдә йолдызлар чыккан, мине югалтып, әнкәйләр эзләргә керешкән иделәр инде.* Ф.Яхин

24) Авыру, ял һ.б.ш.дан соң яңадан көндәлек хезмәт бурычларын үти башлау. *Аягына ныклап басып өлгергәнче үк эшкә чыкты Гайния.* Н.Әхмәдиев. *Кыз икенче көнне үк эшкә чыкты.* Ф.Яруллин

25) Катнашу, кушылу (мәс., ярышка). *Яшь җырчылар бәйгегә чыкты.* Кызыл таң

26) Ел фасылына килеп җитү, берсеннән икенчесенә күчү. *Квартир хакы түләр чак җитә, язга чыгып баралар, балаларга өс-баш, аяк киеме юнәтергә кирәк.* А.Гыйләҗев. *Җәйгә чыккач, ат ашатырга барганда, икмәк сыныгы белән янәшә куенымда берәр китапчык та була иде.* Г.Бәширов

27) Сизелә башлау, тоелу, таралу (ис, бу, җылылык һ.б.ш.). *Бөтен өй эченә кыздырылган тәмле ит исе чыкты.* Н.Фәттах. *Йортның ишеге, хуҗаларның күңеле киңлеген раслап, киерелеп ачылган, морҗасыннан, каен тузы янган тәмле ис таратып, юаш кына төтен чыга.* А.Гыйләҗев

28) Берәр урында хасил булып яңгырау, таралу (авазлар, тавыш тур.). *Йортта халык йөргәне күренә, әллә нинди тавышлар чыга.* Г.Ибраһимов

29) Әйтелү, ишетелү. *Тын кысылды, Авыз суы кипте, Уен-көлке чыкмый бер сүз дә.* Г.Афзал. *Таһирның кан тулышкан авызыннан ыңгырашып-иңрәп бердәнбер сүз чыкты: – Ф-ф-а-ш-ш-ист...* Г.Гыйльманов. *«Туйдым мич башында ятудан, сиңа барып булышасым килә», – дияргә теләгән иде, авызыннан икенче сүзләр чыкты.* З.Хөснияр

30) Чәй кайнар суда тиешле дәрәҗәгә җитеп пешү, тәмен һәм төсен бирү. *Чәе яхшы чыккан.* Җ.Юныс

31) Нәрсәдә дә булса катнашудан туктау. *Бу вакытта аның да күңеленнән хәсрәте китеп торган, Кәримәсе уеннан чыккан, поездда өйгә кайтып бару шатлыгы гына иде югыйсә.* Ф.Яхин. *Элек, субсидия алу өчен, гаилә составы турында белешмә, шулай ук, аның үзгәрү сәбәпләрен, гражданнарның гаилә составыннан чыгуын документлар белән раслау, гариза бирүче белән бергә яшәүчеләрне гаилә әгъзалары дип тану турында суд актлары күчермәләре һәм тагын әллә күпме документлар таләп ителде.* Кызыл таң

32) *сөйл.* Берәр урында эшләүдән туктау, эшләүне ташлау. *Нәҗия, хезмәттән чыккач, үзен читлектән ычкынган кош кебек тоя башлады.* Ә.Еники

33) Берәр төрле физик яки рухи халәттән арыну, котылу. *Бу халәттән чыгарга, дөнья күрүгә сусаган күзәнәкләрне тутырырга, киң колач белән йөрергә, яшәргә кирәк иде.* М.Мәһдиев. *Кайгыдан чык – Күзеңне томалаган, Акылың ач – Бәхетең чорнап алган.* Ф.Яхин

34) Физик үсешнең билгеле бер чорына хас үзлекләр, сыйфатлар бетү, юк булу. *Балалыктан чыгып җитмәгән, бит алмалары кызарып, чокырланып торган бу кызның сораулары шулхәтле самими иде, Урманов теләсә-теләмәсә дә көлемсерәп куйды.* Г.Әпсәләмов. *Ә Мансур дигәннәре бөтенләй япь-яшь, үсмер малайлыктан чыгып килгән егет кенә, үзе бик оялчан да булса кирәк, минем белән күрешкәндә, нәкъ кызлар төсле, ияк очына кадәр кызарды.* Ә.Еники

35) Срок, вакыт һ.б.ш. бетү, узу, ахырына җитү. *Элеккеге кебек үк, аның көннәре подразделениеләрдә үтә, ләкин хәзер, командировкасының срогы чыккач та, ул редакциягә кайтырга ашыкмый иде.* Г.Әпсәләмов. *Солтан аны көтте-көтте дә, инде вакыты чыккач, план-проспектын берничә нөсхәдә Сабир Кәшфиевичтә калдырып китте.* Ф.Яхин

36) *сөйл.* Уку йортын тәмамлау, уку йортында укудан туктау. *Мәдрәсәдән чыкканчы, Җәләлгә аның белән узышырга, үзен шуңардан шәп итеп күрсәтү өчен тырышырга туры килде.* Г.Ибраһимов

37) Иҗтимагый тормышның яңа шартларына күчеп эшли һәм яши башлау. *Без, социализм төзибез, гомуми хөррияткә чыгабыз, байлык эчендә йөзәчәкбез дип, илнең гасырлар буе тупланган малын-байлыгын әрәм-шәрәм итеп, бер мәртәбә нык ялгыштык бит инде.* Ә.Борһанов

38) Актив эшчәнлектән ялның нинди дә булса төренә күчү. *Һашим, шушы йомык күзле төрмәдә утыз өч ел гомерен калдырып, пенсиягә чыккан иде...* А.Гыйләҗев. *Җәйге ялга чыкканнан соң, аның Сөмбелне күргәне-очратканы да юк.* А.Хәлим

39) Башлану, күтәрелү (җил, давыл һ.б.ш.). *Көндез бераз аязытып торса да, хәзер җәяүле буран чыккан...* А.Гыйләҗев. *Каяндыр көчле җил чыгып, юкәнең куе ябалдашларын шаулатып йолкый башлады.* Г.Гыйльманов

40) Берәр нәрсәнең башлангычы барлыкка килү, башлану. *Әбинең уллары-кызлары үсә төшеп, кул арасына керә башлагач кына, сугыш чыга.* В.Нуруллин. *Атналар-айлар буена кешеләр бер-берсенә бәрелеп-ышкылып яшәгәч, алар арасында ызгыш-талаш та чыгып киткәли.* Ә.Еники

41) Берәр нәрсәнең нәтиҗәсе буларак барлыкка килү. *Айгыр мәсьәләсендә бераз комачаулык чыкты.* М.Галәү

42) Нинди дә булса эш-хәрәкәт нәтиҗәсендә берәр төрле хәл хасил булу; берәр төрле халәт, күренеш барлыкка килү

43) Табылу, килеп чыгу; мөмкинлек, шартлар туу. *Рабочком председателе Корнишинга ашыгыч эш чыкты.* А.Алиш. *Ул әллә кемнәрдән өшкертеп китертсә дә, файда чыкмады.* Г.Исхакый

44) Тумышы белән берәр халыктан, урыннан яки социаль катлаудан булу. *Фәхри авылдан чыккан, хәзерге көндә татар авылының активистларыннан булып, башка шундый күп активистларныкы кебек үк, моның да биографиясе бик гади.* Г.Ибраһимов. *Соңгы егерме ел эчендә безнең колхоздан күпме белгечләр чыкты.* Т.Гыйззәт

45) Берәр социаль катлаудан аерылу. *Соңрак аларга ярлы гаиләдән чыккан яки байларда асрау булып эшләгән кызлар да кушылган.* Ә.Еники

46) Берәр берләшмәдә, оешмада әгъза булудан туктау, шуның эшенә катнашмый башлау. *Җилсин дә шул партиядән чыкты түгелме соң?* Л. Лерон. *Ә сектадан чыгу – тормышка аша алмаслык хыял.* Безнең гәҗит

47) Берәр төрле шәхес булып формалашу, берәр төрле кеше булып әверелү. *Тик Карипнең, аны күреп: «Малайны әрәм итмә, Салах абзый, аңардан яхшы кеше чыгачак», – дигән сүзләренә каршы, көлемсерәп кенә: «Әйдә укысын, укысын, аның бер эше дә юк», – дип җавап кайтарды.* А.Алиш

48) Басылу, нәшер ителү. *Ярар, бу елда башка телләрдә күп китапларыбыз чыкты ди.* М.Хуҗин. *Патша сараеның матбугат органы эшләп килә: бәйрәм саен конторда, мәктәптә, савымчылар йортында һәм автопаркта даими рәвештә стена газеталары чыга.* К.Кәримов

49) Гамәлгә кертелү, халыкка игълан ителү (закон һ.б.ш.). *Приказ чыккан, цехка кертмиләр, сөйләшеп аңлашыр кеше дә юк.* Ә.Еники. *1773 ел. Бу елны дин иреге турында Әби патшаның фәрманы чыга.* Р.Батулла

50) Иҗат ителү, иҗат процессында барлыкка килү. *Машинага карап шигырь чыкмый.* Г.Афзал. *Кайттым картлыгымда, Туган туфрагымда Йөрәгемнән мәхзүн җыр чыга.* И.Юзеев. *Күңелнең мең дә бер кылы тартыла да, җыр чыга!* М.Мәһдиев

51) *сөйл.* Ясалу, эшләнеп барлыкка килү. *Кызларга яңа модалы кием чыкты.* Яшел Үзән

52) Халык алдында, аудиториядә берәр хәбәр сөйләү, белдерү, чыгыш ясау. *Болардан тыш, Г. Рәхим Татарстанны өйрәнү җәмгыятендә һәм гыйльми үзәктә күпсанлы докладлар белән чыга, рецензияләр яза, тәрҗемәчелек белән шөгыльләнә.* М.Мәһдиев. *Икенче көнне күмхуҗның идарә утырышында Сабирҗанны завхозлыктан куу тиешлеге хакында озын-озак дәлилле һәм дәлилсез нотык белән чыгып, рәиснең ризалыгын алган.* Ф.Яхин

53) Кемгә яки нәрсәгә дә карата үзеңнең фикереңне, мөнәсәбәтеңне ачыктан-ачык белдерү. *Ул аяк-кулы белән уртак карарга каршы чыкты, арадан бер-ике кеше аны куәтләде, әмма күпчелек һәрчак җиңә: аларның фикере шау-шу арасында күмелеп тә калды.* А.Гыйләҗев. *Шагыйрьнең тарихка мифологик ышанулар аша килүен шул чорда ук олуг тарихчы З.Вәлиди дә хуплап чыга.* Казан утлары

54) *күч.* Бер якны ташлап, икенче якка кушылу, күчү. *Бик азлары гына үзләре теләп дошман ягына чыккан...* Г.Әпсәләмов

55) *күч.* Баш тарту, тотмый башлау (дин тур.). *– Үзегез һәлак булгансыз-булгансыз инде, зинһар, мине генә чиркәүгә алып бармагыз, зинһар, мине генә көчләмәгез, асыгыз, кисегез, мин диннән чыкмыйм! – дип үкереп елый һәм автомобильдән төшәргә тырыша иде.* Ф.Әмирхан. *1905 елның апрелендә, дин тоту ирege бирелгәч, күп крестьяннар христианлыктан чыгу турында үтенеч биргәннәр.* Тормыш // Икенче дингә күчү. *Христианлыктан чыгып исламга килү*

56) *күч.* Бик күпләргә билгеле булу, таралу (хәбәр, дан һ.б.ш.). *[Сәрбиҗамал:] Яратмасам да, әби, бу – бик зур оят эш бит, кеше күзенә нихәл итеп күренерсең. Кеше арасына исемем чыкса, нишләрмен?* Г.Камал. *Бөтен тирәякта ат тану белән даны чыккан Гәрәй картның күзенә бу елкылар эчендә начар гына, ябык кына бер тай чалынган.* Г.Гыйльманов

57) Берәр максат белән нинди дә булса аппарат, җайланма һ.б.ш. аша үтү; шуның белән эшкәртелү. *Картының нәкъ шушы вакытта урман аланында сәер кунагы белән бәрәңге пешереп ятканлыгын белеп алган Хәерниса түти яңа гына сепараттан чыккан каймагын әзерләп куя.* Ф.Яруллин

58) Берәр нәрсә табылу; булуы билгеле булу, ачыклану. *Ахырда, уйлаша торгач, башта Суфиян, аннары Гөлбикә дә яшел сандыктан чыккан бөтен киемсалымны театрга илтеп тапшырырга риза булдылар.* Ә.Еники. *Аңа, нишләптер, үзе казыган чокырдан бихисап хәзинәләр чыгар кебек тоела.* А.Хәлим

59) Җир астыннан алыну (файдалы казылмалар тур.). *Бакыр чыкмас җирдән алтын эзләмә.* Әйтем. *Татарстанда кара алтын чыга, шуның белән никадәр яңа завод-фабрикалар сафка баса башлаган вакыт.* Н.Әхмәдиев

60) Тотылу, эләгү (балык тур.). *Ике вагонлап балык чыккан иде.* Ш.Камал

61) Туры килү; эләгү, тию. *Ә ул киләсе кичне җиңги, амбардан ит алып кайтып, бик шәпләп аш пешереп куя, һәм, әлбәттә, миңа да өлеш чыга.* В.Нуруллин. *Ел саен алты-җиде йөз сумлык билет алам, биш-алты тәңкәлек отыш чыга.* Р.Батулла

62) Берәр нәрсәгә нигезләнеп фикер йөртү, шуңа таянып эш итү. *Инде чыннан да мондый дәлилдән чыгып фикер йөртсәк, хайваннарның һәм үсемлекләрнең яңа төрләрен, клонлаштыруны, генетиканы һәм гомумән фәнне дә, теләсә нинди иҗатны да Аллаһ Тәгаләгә тиңләшергә тырышу дип санарга кирәк.* Казан утлары

63) Берәр нәрсәнең сәбәпчесе булу, чыганагы булу (сүз, гайбәт һ.б.ш. турында). *Миннән чыккан сүз түгел бу*

64) Сарыф ителү, тотылу (акча һ.б.ш.). *Бу йортыңда берәр балаң Гомер итәр микән соң? Берни белмим. Әле анда – Тик таш тезгән өемдер... Биниһая чыгым чыга. Мәшәкать күп, гомер – бер!* К.Булатова. *Интернатта одеял, урын-җир япмалары, тастымаллар, сабын-порошоклар – барысы да бар, сатып ала башласаң, әллә күпме акча чыга.* К.Кара

65) Берәр ир белән тормыш кору, аның хатыны булу (гадәттә *кияүгә, иргә, тормышка* сүзләре янында). *Зәйнәп Рәшиткә кияүгә чыкты.* З.Хәким. *Бераздан әнием икенче иргә чыкты.* Ф.Яруллин. *Ул өйләнгән кеше булган, аның хатыны Себердә, ул инде кабат тормышка чыккан.* Г.Гыйльманов

66) Йомыркадан чебеш, бала яралу, барлыкка килү (кошлар, җир-су хайваннары һ.б.ш. тур.). *Өч йөз күкәйдән өч йөз чебеш чыга.* Ф.Яруллин. *Һәр елны ул кайтышка бәпкәләр чыккан була.* В.Нуруллин

67) Нәрсәнеңдер җавабы табылу. *Эзли торгач, бу сорауның җавабы чыкты*

68) Читләшү, читкә китү. *Темадан чыгу*

69) Коръәнне, нинди дә булса сүрәне башыннан ахырына кадәр тулысынча уку. *Дәрвиш коткарды улыңны, Коръән чыккан дәрвиш.* М.Хәбибуллин. *Кем өшкерде, кем «Ясин» чыкты, кем даруын, үләнен бирде – барысы да үлеп яткан бала тирәсендә бөтерелде.* Ф.Бәйрәмова

70) Эш-хәлнең билгеле бер нәтиҗәгә килүен белдерә. *Ләкин бу мәшәкатьләр бушка чыкмады: мулла кияү белән Саҗидәне парлап ашка чакыра башладылар.* Г.Исхакый. *Бабайның сүзе чыннан да дөрескә чыкты.* Г.Әпсәләмов

**2.** *ярд. ф. функ.* 1) Бик күп предметларга юнәлгән эш-хәрәкәтнең эзлекле үтәлүен белдерә. *Шуннан соң гына Карп Васильевич Газинурны игътибар белән баштанаяк карап чыкты.* Г.Әпсәләмов. *Габделбәр барысының да чаңгы йозакларын тикшереп чыкты.* А.Хәсәнов

2) Эш-хәрәкәтнең башыннан алып ахырына кадәр үтәлүен, башкарылуын белдерә. *Ул, озын керфекләр белән каймаланган үтә ялтыравыклы соры күзләрен кыса төшеп, телеграмманы укып чыкты.* А.Гыйләҗев

3) Нәтиҗәле эш-хәрәкәтне белдерә. *Сөт кайнап чыкты* // Тулысынча, кайтаргысыз рәвештә башкарылган эш-хәрәкәтне белдерә. *Сумка бавы өзелеп чыкты*

4) Билгеле бер урында, пространство чикләрендә барган эш-хәрәкәтне белдерә. *Райүзәкнең бер генә урамына тезелешкән эреле-ваклы кибетләрен йөреп чыга.* Ә.Еники

5) Нинди дә булса вакыт аралыгында дәвам иткән эш-хәрәкәтне белдерә. *Ике көн, ике төн буена Козьма кичәге хаким гәүдәсен утын сараенда саклап чыкты.* В.Имамов

6) Көтелмәгән яки кинәт башкарылган эш-хәрәкәтне белдерә. *Әниемнең сул як яңагы шешеп чыккан икән, әле генә күрдем.* А.Гыйләҗев. *Кайчак тормышта адәм ышанмаслык хәлләр дә килеп чыккалый.* А.Тимергалин

◊ **Чыкмаган җаны гына (бар)** Бик хәлсез һәм чирле яки карт кеше турында. *Зифа карчыкның тик чыкмаган җаны гына бар иде.* Г.Ибраһимов

**Чыга башлау** Чыгарга тотыну. *Заводның кызыл кирпеч стеналары*

*капкасыннан эш киеме, блузалар, кепкалар, шәлләр, бүрекләр кигән эшчеләр чыга башлады.* А.Алиш

**Чыга килү** Күптәннән, эзлекле рәвештә чыгу. *Газеталар даими чыга килә*

**Чыга тору** Нindидер эш, процесс башлангычы, шуны көткән арада чыгу; һаман чыгуы дәвам итү. *Ләкин бүген кичкә каршы бер-бер артлы мәшәкатьләр чыга торды.* Г.Ибраһимов. *Яңа авырулар да кабул ителде, терелгәннәре чыга торды, операцияләр дә ясала торды.* Г.Әпсәләмов

**Чыга төшү** Бераз чыгу; тагы да чыгу. *Кыз ишектән чыга төште*

**Чыгып бару** Берсе артыннан берсе чыгу, эзлекле рәвештә чыгу. *Теплоход причалдан ераклашкан саен, кояш та болыт астыннан күбрәк чыга барды.* Г.Әпсәләмов

**Чыгып бетү** Барысы да чыгу. *Яшьтәшләр һәммәсе кияүгә чыгып бетте!..* А.Гыйләҗев

**Чыгып калу** Чыгарга өлгерү. *Галимнең китабы гарәп язуында чыгып калды*

**Чыгып карау** Сынау, нәрсәнедер белү-тикшерү максаты белән чыгу. *Җимерек күпер аша чыгып карау*

**Чыгып килү** Күптәннән эзлекле рәвештә чыгу. *Газета бернichә ел рәттән чыгып килә*

**Чыгып тору** Даими чыгу; сөйләү моментында чыгу

**Чыгып яту** *сөйл. к.* **чыгып тору**. *Зәй елгасының сул ягында сузылган текә таулар итәгеннән күпсанлы чишмәләр чыгып ятканнар.* З.Зәйнуллин

**ЧЫГУ́-ЧЫГЫШКА** *рәв.* Чыккач ук, чыгар-чыкмас. *Алар чыгу-чыгышка очраштылар*

**ЧЫГЫМ** I *и.* 1) Берәр максат белән тотылган, сарыф ителгән акча, малмөлкәт; расход, хәреҗ. *Безнең бит эшләр күп, чыгымнар зур!* Ф.Яхин. *Барлык чыгым алардан булды, ди әни.* М.Хуҗин. *Эшкәртмичә, тир түкмичә, чыгым чыгармыйча гына ипекәй алырга.* Ф.Садриев

2) *махс.* Нәрсәнең дә булса аркылы кисеме аша бер секунд эчендә агып үтә торган сыеклык күләме, *русчасы:* **расход**. *Агыйдел – Кама елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 1430 км (Татарстандагы өлеше 76 км), тамагында су чыгымы 950 куб м/с.* А.Тимергалин. *Интернет киңлеген тикшергәндә, су чыгымы, электр энергиясе, газ исәпләгечләрен туктату һәм аларның пломбаларын ачу юлы белән урлау ысуллары турында мәгълүмат урнаштырган сайтларны ачыклаган.* Кызыл таң

**ЧЫГЫМ** II *с. диал. к.* **чыгымчы**. *[Нәҗип:] Кара, бу чыгым тай да тәртәгә кердемени?* Г.Гобәй

**ЧЫГЫМЛАНУ** *ф.* Нәрсәгә дә булса акча, мал тоту, сарыф итү; расходлану. *Дөрес, без бу артуны җылыту сезоны башлангач кына сизәчәкбез: быелдан башлап, җылылык өчен кышын гына чыгымланып, җәен түләми башладык бит.* Сөембикә. *Бер генә ил дә моның кадәр күп чыгымланмый.* Безнең гәҗит

**ЧЫГЫМЛА́У** *ф. диал. к.* **чыгымчылау**. *Начар, холыксыз, бер дә юктан гына чыгымлый торган бахбайларга юлыкканда, әти ашаудан кала, йокысы кача.* А.Хәсәнов

**Чыгымлый башлау** Чыгымларга тотыну. *Тауга каршы бер җирдә, шушы исерекләрне тарта алмау хурлыгыннан, Матур чыгымлый башлаган.* Н.Гыйматдинова

**Чыгымлап йөрү** Берникадәр вакыт чыгымлау. *Башкалар кебек чыгымлап йөрмәде, кергән көненнән алып сугыш чыкканчыга хәтле күмәк хуҗалыкта атлар карады.* З.Зәйнуллин

**Чыгымлап кую** Бераз чыгымлау. *Аска карагач, йөрәк чыгымлап куя, хәл кыенлаша...* Т.Нәҗмиев

**Чыгымлап тору** Даими, гел чыгымлау; хәзерге вакытта чыгымлау. *– Хәзрәт, кыз чыгымлап тора, нишлибез? – диде.* М.Мәһдиев

**ЧЫГЫМЛЫ** *с.* Күп чыгым (I) таләп итә торган, күп чыгым ясарга туры килә торган; расходлы. *Мәктәп чыгымлы: каләме, дәфтәре, сумкасы кирәк.* Н.Гыйматдинова. *Әти-әни, кайнатам белән кайнанам да туган-үскән җирләрен сагыналар, безгә шуны гел искә төшереп сөйлиләр иде. Әмма, бердән, тормыш басты, икенчедән – юл ерак, чыгымлы, күпме сагышлансалар да, Чүтине бер кайтып күрә алмадылар.* Т.Әйди

**ЧЫГЫМСЫЗ** *с.* **1.** Чыгым (I) таләп итми торган; чыгымы аз булган. *Чыгымсыз эш түгел, шактый кыйммәтле җайланмалар сатып алырга туры килде.* Ватаным Татарстан

**2.** *рәв. мәгъ.* Чыгымланмыйча, чыгым (I) чыгармыйча; күп акча түкмичә. *Тормыш итә башлаучы яшь пар гомеренең соңгы көненә кадәр истә калырга тиешле көнне мөмкин кадәр күңелле, шул ук вакытта чыгымсыз үткәрергә тели.* Сөембикә

**ЧЫГЫМЧЫ** *с.* 1) Чыгымчылый торган (ат тур.). *Хәер, атны да, өйрәтә белмәсәң, чыгымчы булыр, ди.* А.Тимергалин. *Ләкин берсен дә тыңламадым, чыгымчы ат шикелле тереләдем дә каттым...* В.Нуруллин

2) *күч.* Киреләнүчән, тискәре, кәҗәләнүчән (кешегә карата). *Чыгымчы холыклы ул хатын сиңа тагын кайгы гына булачак.* Р.Батулла. *Исәбе буенча, чыгымчы ирне тынычландыру максатыннан кулланыла торган мондый алымнар гаилә тормышын көйләп-майлап җибәрергә тиеш иде кебек.* Г.Әдһәмова

**ЧЫГЫМЧЫЛА́У** *ф.* 1) Юлда алга бармау, киреләнү, үҗәтләнү (ешрак җиккән ат тур.)

2) *күч.* Киреләнү, тискәреләнү; кәҗәләнү. *Ир бик нык чыгымчылады*

**Чыгымчылап алу** Бераз чыгымчылау. *Менә минем Шакирым да чыгымчылап алды, шуңа гына әйтүем.* Г.Галиева. *Светлана кайчак яшьлеге белән чыгымлап алса да, Коръәнне укыгач, минем хаклыкны таный.* Шәһри Казан

**Чыгымчылап йөрү** Билгеле вакыт чыгымчылау. *Нәфисә дә үзгәрер әле, гел болай чыгымчылап йөрмәс...* Г.Гыйльманов

**Чыгымчылап тору** Даими, гел чыгымчылау; әле, хәзер чыгымчылау. *Ат та, нидер сизенгәндәй, ул якка барырга теләмичә, чыгымчылап торды...* М.Хәсәнов

**Чыгымчылый башлау** Чыгымчыларга тотыну. *Тракторлар гүләве көчәя барып, бу ят тавышны гомерендә беренче тапкыр ишеткән ат каты куркуга төште, чыгымчылый башлады.* С.Рафиков

**ЧЫГЫНКЫ** I *с.* Берәр яссылыктан беркадәр чыгып торган, калку. *Безне кабул итеп алган чыгынкы яңаклы, саргылт чәчле өлкән лейтенант Фунтиков, минем Актаста бригадир булуымны белгәч: «Монда да бригадир булырсың!» – диде, читтәрәк басып торырга кушты.* А.Гыйләҗев. *Баш түбәсенә сыя алмагандай тырпаеп торган куе, каты чәчле Җәүдәт чыгынкы маңгае астыннан сынап карады.* М.Маликова

**ЧЫГЫНКЫ** II *с. диал.* Мул, бик күп, кирәгәннән артык (тоз тур.). *Казылык итнең тозы чыгынкы булырга тиеш*

**ЧЫГЫНКЫЛАНУ** *ф.* Чыгынкы (I) хәлгә килү, чыгынкыга әйләнү. *Шеш, гомумән, кабарып, очлаеп, чыгынкыланып торган урын, дип тасвирлана.* Сөембикә

**ЧЫГЫНКЫЛЫК** *и.* Чыгынкы (I) урын. *Маңгайның чыгынкылыгы*

**ЧЫГЫНТЫ** *и.* Берәр нәрсәнең бер өслектән чыгып, калкып торган урыны. *Егылмаска диеп, таш кыяның Тик бер чыгынтысын эзлисең.* Ф.Дәүләтгәрәева. *Күзәнәк өслегендә тышкы тәэсирләрне кабул итүче сизүче чыгынты урнаша.* Биология

**ЧЫГЫР** *и.* 1) Үз күчәрендә әйләнә торган улаклы көпчәгенә аркан, чылбыр һ.б.ш. тагылган гади йөк күтәрү җайланмасы. *Мотордан чыккан электр көче корыч арканга бәйләнгән бабаны чыгыр буенча югары өстери.* А.Алиш

2) Коедан чиләк белән су чыгару өчен, үз күчәрендә әйләнә торган саплы йомры борыстан гыйбарәт җайланма. *Майламаган чыгыр шыгырдый, чыгыр баганалары дер-дер киләләр, күңелемдә шатлык катыш ниндидер хафа бар.* А.Гыйләҗев. *Әле һаман күз алдымда Сиртмәле кое тора, Чыгырларның шыгыр-шыгыр Шигырьдәй көе тора.* И.Юзеев

3) *тех.* Зур булмаган мәйданнарны сугарганда, берәр сулыктан су күтәрү өчен, чумыргычлар беркетелгән көпчәктән гыйбарәт гади җайланма; *рус-часы:* **чигирь**. *Чыгыры да какшау, көчхәл белән сыңар чиләк суны чыдата иде.* А.Гыйләҗев

4) Балага тәпи йөрергә өйрәнү өчен, дүрт яктан киртәләп эшләнгән кечкенә арба. *Йосыф абый бура бурарга оста иде. Олы малае Тимербай абый «нечкә» эшләрне дә булдыра. Аның балалар чыгыры ясавы турында алдарак язылды.* М.Хуҗин

5) Нинди дә булса авыр әйберне урыннан күчерү өчен кулланыла торган кечкенә тәгәрмәч, ролик. *Рояльне чыгыр ярдәмендә күчердек*

◊ **Чыгырдан чыгару** 1) Бик нык ачуны китерү, бик нык ачуландырып, ярсытып, үз-үзен тота алмаслык дәрәҗәгә җиткерү. *Бу сүзләр Сөмбелне тәмам чыгырыннан чыгарды.* З.Кадыйрова; 2) Тормышның, эш барышының гадәти, нормаль хәлен тәмам бозу, җимерү. **Чыгырдан чыгу** 1) Бик нык ачулану, бик нык ачуланып, кызып китеп, үз-үзен тота алмаслык дәрәҗәгә җитү, белештерми башлау. *Ул тәмам чыгырдан чыкты.* М.Мәһдиев. *Берара, тәмам чыгырдан чыгып, тимер чылбырын зәһәрләнеп чәйнәп, котырып ала.* А.Хәсәнов; 2) Нәрсәнең дә булса нормаль эшчәнлеге бозылу, эшләми башлау; җимерелү. *Аккүз дә чыгырыннан чыккан. Телен асылындырып, еш-еш сулап, хуҗасы янәшәсендә ята.* Г.Гыйльманов

**ЧЫГЫРЛЫ** *с.* Чыгыр (*3 мәгъ.*) ярдәмендә су алына торган (кое). *Безнең якта, йортыбыздан башка, тагын тәгәрмәч чыгырлы кое торып калды.* Ә.Еники. *Суны һаман чыгырлы коедан алалар.* А.Гыйләҗев

**ЧЫГЫ́Р-ЧЫГЫР** *иярт. к.* **шыгыр-шыгыр**. *Чыгыр-чыгыр иткән ишек тавышы да өйдәшләрнең торуларын белдерә иде.* Г.Исхакый. *Ул агач калаклары белән ишә-ишә, көймәсенең майланмаган тәгәрмәчләре белән чыгыр-чыгыр китеп тә барды.* Казан утлары

**ЧЫГЫШ** *и.* **1.** 1) Берәр бина, корылма һ.б.ш.дан чыгу урыны, чыгу юлы. *Чыгышта тоткарлану*

2) Берәр эшне төгәлләү, бетерү вакыты. *Мунчадан чыгышына чәй әзерләү*

3) Берәр нәрсәнең алынган урыны, чыганагы. *Григорийга Лукьян өстендәге искереп беткән чикмәннең чыгышы кайдан икәнен аңлау һәм шул уңайдан бераз нәрсәләр турында уйланыр өчен бу сүзләр җитә калды.* Ш.Камал

4) Үзенең тумышы, сыйнфый хәле белән нинди дә булса катлауга, сыйныфка караган булу. *Авырга алма, Искәндәр, бергә торган чагында мин сине чыгышың, тәрбияң белән шелтәләмәдем.* Г.Кутуй. *Әтисе, чыгышы белән авылдан булса да, шәһәрдә үскән.* Г.Гыйльманов

5) Горизонт өстенә кояш чыккан урын; кояш чыгу тарафы. *Мин аның, кире борылып, бабалары үткән юлдан көн чыгышына кайтуын телим.* З.Хәким. *Яшь солдатлар китә төялеп: Берсе – кояш чыгышына, Берсе – баешларына.* И.Юзеев

6) Нинди дә булса чималны эшкәрткәндә алына, килеп чыга торган продукт. *Хәзерге заманда, чит ил предприятиеләре белән чагыштырганда, артык зур күрсәткеч түгел, әлбәттә, аларда икенчел чимал чыгышы күбрәк бит.* Кызыл Таң // Иген сукканда мәйдан берәмлегенә карата килеп чыккан ашлык микъдары. *Чәчүгә төшәргә вакыт җитә, келәтләрдә орлык аз. Булганының чыгышы түбән.* А.Гыйләҗев // Тотылган он белән чагыштырганда пешкән икмәкнең микъдары. *Икмәкнең чыгышы күңелдә берникадәр шик тудыра, чөнки узган ел мул уңышка иялә-неп киткән идек.* Шәһри Казан

7) Халык алдына чыгып нәрсә дә булса сөйләү гамәле. *Бүген дә аның чыгышын шыгрым тулы зал гаять зур кызыксыну белән тыңлады.* Г.Әпсәләмов

8) Халык алдына чыгып сөйләнә торган хәбәр, речь, доклад, нотык һ.б.ш. *Чыгышымның текстын һәм шигырь китердем.* Г.Кутуй. *Мәхмүтнең чыгышы бик коры иде, аны юньләп тыңлаучы кеше дә булмады, ахры.* Г.Гыйльманов

9) Халык алдында, мәсәлән, сәхнәдә берәр нәрсә башкару; халык алдында, сәхнәдә башкарылган яки башкарыла торган җыр, бию һ.б.ш. *Фестиваль лауреатлары Кремльнең Съездлар сараенда йомгаклау концерты белән чыгыш ясарга тиешләр икән.* К.Кәримов

10) Нинди дә булса формада белдерелгән көчле ризасызлык, протест. *1919 елның 25 июнендә Казанда татар-башкорт запас батальонындагы баш күтәрүчеләрне буйсынырга өндәп чыгыш ясаганда атып үтерелә.* Г.Ибраһимов

11) Пешә алу сыйфаты, сыгынты бирү сәләте (чәй тур.). *«Ахмад» маркалы чәйнең чыгышы бик әйбәт икән.* Н.Көбәш

**2.** *с. мәгъ.* Нәрсәнең дә булса башлангычы яки нигезе итеп алына торган яисә алынган. *Кояш инде чыгыш нокталан баш очыма килеп туктаган.* Р.Фәйзуллин

**ЧЫГЫ́Ш КИЛЕШЕ** *и. лингв.* Эш яки хәлнең гадәттә урын, вакыт ягыннан башлану ноктасын белдерә торган грамматик форма (мәс., *урманнан, иртәдән*). *Чыгыш килеш күрсәткече алган сан беренче урында, баш килешгәгесе аннан соң әйтелә.* Татар грамматикасы

**ЧЫГЫШЛЫ** *с.* 1) Яхшы пешә торган, сыгынтысы яхшы чыга торган (чәй тур.). *Аның каравы чыгышлы һинд чәен йөзеп китәрдәй булып эчте.* К.Кара

2) Тууы, чыгышы белән билгеле катлау, халык, дәүләт һ.б.ш.дан булган. *Морза чыгышлы Әмирхан Еникиләр, тумыштан затлы Гомәр Бәшировлар киткәч, татар дөньясы рухи аристократларсыз – рульсез калды.* А.Тимергалин

**ЧЫГЫШЛЫЙ** *рәв. сөйл.* Каян да булса чыкканда, чыгып барганда, чыгу уңаенда. *Мунчадан чыгышлый, безнең авылда тәртип шундый: хуҗаның ишеген кагасың, хуҗа чыккач, рәхмәт әйтәсең.* М.Мәһдиев. *Бүлмәдән чыгышлый, ишек янындагы дәү көзгегә күз салды.* Н.Хәсәнов

**ЧЫГЫШСЫЗ** *с.* **1.** 1) Авыр, чыгу юлы күренмәгән, котылып булмаслык,

чарасыз. *Бу – шәһәрләрдә яшәп, өеннән урамга чыгу белән үк урыс телле мохиткә эләгә торган татарларның хәле кебек үк чыгышсыз тоела миңа.* Татарстан яшьләре

2) *сөйл.* Начар пешә торган, сыгынтысы начар чыга торган (чәй тур.). *Һәммә нәрсәнең җае бар аның: чыгышсыз чәй белән прахутта нишләмәкче буласың... алай түгел ул.* Мәйдан

3) *күч.* Тәэсирсез, ятышсыз, начар. *Чыгышсыз, мантыйксыз һәм эчке мәгънәсе ябышмаган җөмләләр бәетләрдә бик күп.* Г.Рәхим

**2.** *рәв. мәгъ.* Чыгыш (*8 мәгъ.*) ясалмыйча. *Конференциядә чыгышсыз катнашырга*

**ЧЫДАМ** *с.* **1.** 1) *к.* **чыдамлы**. *Әйтәсе юк: мәрхүм бик сабыр холыклы, чыдам кеше иде...* Ә.Еники. *Юлга йөрерлеге калган шушы дүрт бөртек чыдам ат булмаса, без нишләр идек икән?* А.Гыйләҗев. *Татарлар – чыдам халык.* Г.Гыйльманов

2) Берәр физик, химик һ.б.ш. тәэсиргә бирешми торган, шуңа чыдый торган. *Борынгы телдә шулай ук бакыр нигезендә ясалган утка чыдам эретмә – «кула» сүзе дә булган.* А.Тимергалин. *Тутыргыч урынына, суга чыдам бетон ясаганда, коллоидлы беректергеч урынына, каты суны йомшарту өчен, кою калыплары әзерләгәндә кулланыла.* Төзү материаллары

**2.** *и. мәгъ. к.* **чыдамлылык**. *Кабакны утыртуын утыртырсыз, ә карап үстерергә чыдамыгыз җитәрме?* Ә.Еники

◊ **Чыдамнан чыгу** Түземлек бетү, артык түзеп тора алмау. *Бервакыт мин, чыдамнан чыгып, бар көчем белән тегене этеп җибәргән идем – уянып киттем!* Ш.Камал

**ЧЫДАМЛЫ** *с.* **1.** 1) Физик яктан нык, бирешмәүчән. *Ул таза, чыдамлы, уңган чын игенче иде.* К.Тинчурин

2) Авырлыклар, күңелсезлек һ.б.ш.ны зарланмыйча һәм бирешмичә кичерә ала торган, кичерергә сәләтле, түземле. *Мондый нәзберек кешеләр каты сынауларда чыдамлы булмыйлар, тиз сыгылалар, бигрәк тә сынауда ялгыздан ялгыз калгач тиз бирешүчән булалар.* Г.Әпсәләмов

3) Яхшы эшләнгән, яхшы ясалган; нык (эшләнмәләр тур.). *Мидхәтнең Әнисә хакында сорашасы килә, ләкин нидер тыя иде. Кызның исемен әйткәндә тавышы калтырап китәр шикелле... Үзе, карашын аска төшереп, прилавкада яткан оекбашларны сыйпаштырды. – Менә болары әйбәт, чыдамлы.* М.Маликова

4) *махс. к.* **чыдам 1.** (*2 мәгъ.*). *Утка чыдамлы кирпечләрнең суынганын көтсәң, өч-дүрт смена вакыт үтә.* Н.Хәсәнов. *Хәзер исә космик кораблар бортыннан Венера планетасы өслегенә төшә алырдай махсус ракеталар проектлана, ә космонавтлар өчен йөзләрчә атмосфералы басымга һәм югары температурага чыдамлы скафандрлар әзерләнә.* Р.Фәизов

**2.** *рәв. мәгъ.* Хезмәт итү вакыты озакка җитәрлек итеп. *Әткәй үзе дә чабатаны бик матур, чыдамлы итеп үрә дә бит, әмма аңа бик күп вакыт кирәк.* Безнең гәҗит

**ЧЫДАМЛЫК** *и. к.* **чыдамлылык**. *Юк, мондый табигате булган, мондый чыдамлыгы булган халык беркайчан да беркемгә дә кол булмас!* М.Мәһдиев. *Аякларның әрнүенә түзәм, бирешмим, Корчагин кебек чыдамлык күрсәтәм!* М.Маликова

**ЧЫДАМЛЫЛЫК** *и.* Авырлыкларны, кыенлыкларны, күңелсезлекләрне һ.б.ш. зарланмыйча һәм һичнәрсәгә бирешмичә кичерә алу сәләте. *Аның бу кадәр чыдамлылыгына ачулары кайнаган гестапочылар егетне аягыннан ыргакка асып куйганнар.* Г.Әпсәләмов. *Без ярый инде, әнкәмнең чыдамлылыгына исем китә.* Р.Миңнуллин

**ЧЫДАМСЫЗ** *с.* Чыдамлы булмаган; түземсез. *Балачакта кеше ялгызлыкка бигрәк чыдамсыз була, аңа иптәш, уендаш, дус кирәк.* М.Маликова. *Аякларындагы кирза итеге шакыраеп каткан, өстендәге кара төрмә бушлаты суыкка чыдамсыз булса да, аны алыштырырлыгы юк, авыл капчыгыннан биштәр ясап, бар мөлкәтен шуның төбенә салып, елый-елый, ашыгыпашыгып атлады.* Ф.Яхин

**ЧЫДАМСЫЗЛЫК** *и.* 1) Чыдамлы булмау; чыдамлылык сыйфатларына ия булмау хәле

2) Түземсезлек, сабырсызлык. *Мин тагын гармун төймәләренә төртеп, шулай көй чыгармакчы итеп тартыптартып алдым, мәчебез, чарасызлыктандыр инде, тәмам шашынып, урамга чыгаручы ишегебездә ярык булса да табарга теләп, чыдамсызлык һәм куәт белән тупсаларны тырнарга тотынды.* Ф.Яхин

**ЧЫДАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **чыдау**. *Юл каткагында чабаталарны чыдатыр хәл юк.* М.Мәһдиев. *Чәч бөртегенең һәрберсе, өзелмичә, бер килограмм авырлыкны чыдата.* Р.Нуруллин. *Ашаганы эченә йокмаган ябык гәүдәне, сыңар кылганга ябышса да, үлән чыдатачак иде.* Н.Гыйматдинова

2) *диал.* Җиткерү, чамалап сарыф итү

**Чыдата алу** Чыдату мөмкинлеге булу. *Мондый затлы елмаю җиңү тантанасын җилкәләре чыдата ала торган кешеләрдә генә була торгандыр.* М.Хуҗин. *21 декабрьгә каршы төндә алар пирамида рәвешендә корылган храмга менә башлаган, һәм иске корылма аларны чыдата алмаган.* Безнең гәҗит

**ЧЫДАТЫРЛЫК** *с.* Чыдата алган; чыдата торган. *Гайсә тыныч, аның озын, таза гәүдәсе хәтта тауны чыдатырлык кебек.* З. Мәхмүди

**ЧЫДА́У** *ф.* 1) Авыртуны кичерә алу, авыртуга түзү. *[Нурдәүләт] Редакциядә башы авыртуга чыдамый эшли алмаган эшләрен өйгә алып кайта иде, аннары институт сабакларын әзерләү, әдәби китаплар уку, шулай ук иҗат итүен дә ташламады.* З.Мурсиев

2) Күңелгә авыр килгән хәлне зарланмыйча һәм бирешмичә кичерү, баштан үткәрү; түзү. *Минем тагын бер теләгем бар: монысын инде һич кичекми үтәргә – тирән елгалар кичәргә, барлык авырлыкларга чыдарга, минем илемне әйләнеп чыгарга һәм эзләргә шундый кешене.* А.Алиш. *Эш терәлсә дә сер бирмәс Игенчеләр-кырчылар, Үз дигәненә ирешер, Кыенлыкларга чыдар – Бакырдан көмеш чыкмас дип, Тынып калмас җырчылар!* Ш.Галиев

3) Тыелу, тыелып тору, үз-үзен тыеп тору. *Мин ничек кенә булса да кычкырмаска, чыдарга булдым.* Г.Бәширов. *Бу көлүне ишетеп, чыдый алмыйча, үз бүлмәсеннән карт әтиләре чыкты.* А. Нәҗми

4) Каршы тору, бирешмәү, түзү. *Ләкин Моратның тимер кыршау кебек кулларына моңа кадәр авылда гына түгел, тирә-юньдә дә чыдаучы кеше юк иде.* Х.Хәйруллин

5) Үзенең бөтенлеген, үзлекләрен саклый алу; тузмау; җимерелмәү; таркалмау. *Каты агач шарт сынар, черегән агач кырык ел чыдар.* Әйтем. *Хром күпкә чыдамый, абыең кайтканчы итекләр черер.* А.Гыйләҗев. *Бер елга куян тиресе дә чыдаган. Бер кышка куян бүрек тә чыдый...* А.Тимергалин

◊ **Чыдап кына тор!** Нинди дә булса эш-хәлнең көчле чагылышын, дәрәҗәсе көчлелеген аңлата. *Бергәләшеп уйный*

*башласак, чыдап кына тор!* Җ.Дәрзаман. **Чыдар әмәл калмау** *к.* **чыдар хәл калмау**. *Чыдар әмәл калмады, бик нык эшләтәләр.* **Чыдар әмәл юк** *к.* **чыдар хәл юк. Чыдар хәл калмау** Бик көчле тискәре тәэсир итү, түзәлмәслек авыр булу. *Банат әби дә, азапланып яткан-яткан да, әрнүенә чыдар хәле калмагач, ярдәмгә өметләнеп, монда килгән.* В.Нуриев. **Чыдар хәл юк** «Түзеп торырлык түгел» мәгънәсендә. *Ә минә су салкынына чыдар әмәл юк.* В.Нуруллин. *Кояш кыздыра, эссегә чыдар хәл юк.* В.Нуриев

**Чыдап килү** Күптәннән, бу вакытка кадәр чыдау. *Моңарчы чыдап килгән баулар, арканнар өзгәләнде, бер чана хуҗасын бәреп китте дә телефон баганасына барып сыланды, капчык ярылды, солы акты...* А.Гыйләҗев

**Чыдап тору** Озак вакыт чыдау; хәзергә, вакытлыча чыдау. *Моңарга ничек хурланмаска кирәк, моңарга ничек чыдап торырга кирәк?* Г.Исхакый. *Билал чыдап тора алмады, шундук суга ташланды, зур-зур колачлар белән эчкәре йөзеп китте.* М.Вәлиев

**Чыдап утыру** *сөйл. к.* **чыдап тору.** *Минем бүтән чыдап утырыр хәлем калмады.* З.Кадыйрова

**Чыдап яту** *сөйл. к.* **чыдап тору.** *Саша тәмәке көйрәтеп кенә юана, йөрәгенә төшә торган сызлауга чыдап ята.* Х.Камалов. *Барый абзый күкрәге януга көчкә чыдап ятты, үлеп салкын су эчәсе килде.* З. Кадыйрова

**ЧЫДАШУ** *ф.* Чыдый алу, чыдамлыгы җитү, түзә алу; тыелу, үз-үзен тыеп тору. *Зәһәрлегенә чыдаша алмаган Мәрхәмбикә үзенең көндәшен, җае чыккан саен, тибенеп ятсын, әмма тиңе белән ятсын, дип мыскыл итте.* М.Хәсәнов. *Көн дә кием алыштырган, маена чыдаша алмаган җитәкче хатыннары янында аның һичшиксез матур булып күренәсе килде.* Х.Ибраһим

**ЧЫЕЛДАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **чыелдау**. *Ишегалдында, чыелдатып, кыраклатып, дуңгыз балалары, тавыклар, күркәләр куып йөриләр.* Г.Бәширов. *Машина тормозларын чыелдатып туктап калды.* М.Шабаев

2) *күч. кимс.* Кыллы музыка коралында уйный белмичә уйнау. *Скрипка чыелдату*

**ЧЫЕЛДА́У** *ф.* 1) Бик нечкә, ачы тавыш белән кычкыру. *Койрыгына бассаң, тычкан да чыелдый.* Мәкаль. *Шунда күгәрчен кадәрлерәк бер кош – шәүләгән – безнең өстебездә әйләнә-әйләнә чыелдарга тотынды.* Г.Бәширов. *Ә диңгез акчарлаклары берни дә булмагандай чыелдыйлар, уйныйлар.* М.Мәһдиев

2) Сызгыруга охшаш нечкә ачы аваз чыгару (җансыз предметлар тур.). *Дәресләр өзелде, укытучылар аһылдашты, ашыгыч ярдәм машинасы чыелдады.* Н.Гыйматдинова. *Машиналарның чыелдап туктаганы, кемнәрнеңдер каяндыр нәрсәдер кычкырганы миңа сәер бер көч өстәгәндәй булды.* А.Әхмәтгалиева

**Чыелдап алу** Кыска гына вакыт чыелдау

**Чыелдап җибәрү** Чыелдарга тотыну, кинәт чыелдый башлау. *«Әни-и!» – дип чыелдап җибәргәнемне дә сизми калдым.* З.Мәхмүди

**Чыелдап йөрү** Озак вакыт чыелдау. *Бикә түти, башын кыйшайта төшеп, әле һаман да чыелдап йөргән шәүләгәнгә карап алды.* Г.Бәширов

**Чыелдап кую** Бер тапкыр чыелдау. *Бу быгырдавыкка сызгыру тавышлары кушыла, нидер чыелдап куя, кемдер җан төбе белән уфылдый...* Г.Гыйльманов

**Чыелдап тору** Бертуктаусыз чыелдау; хәзер, әле чыелдау. *Бала, туктаусыз шыңшып яисә чыелдап торса да, рәхәтләнеп елап китә алмый иде.* Г.Гыйльманов

**Чыелдап чыгу** Билгеле бер вакытны чыелдап үткәрү

**Чыелдый башлау** Чыелдарга тотыну. *Шулай качып котылдык дигәндә генә, өсләрендә әлеге шушы шәүләгән чыелдый башламасынмы!* Г.Бәширов

**ЧЫЕЛДЫК** *с.* **1.** 1) Бик нечкә һәм чәрелдәвек (тавыш тур.). *Сәлимнең төсләре китте, болай да чыелдык тавышы тагын да елаграк ишетелә башлады.* Г.Бәширов

2) Чыелдый торган, нечкә ачы тавыш чыга торган. *Өзек-өзек тавышлар ишетелде, яу якынлашканны белдереп, йөрәкләрне телеп, чыелдык быргылар кычкырды.* Н.Фәттах

**2.** *и. мәгъ.* 1) Чыелдый торган тавышлы кеше яки берәр зат. *Инде шул чыелдык аркасында автобустан сөреп төшерәләр икән, дип шұрләп утырганда, шәһәргә килеп тә җиттек.* Г.Луч

2) *зоол.* Чыелдыкчалар семьялыгыннан кәкре томшыклы, канат өсте көрән, канат асты ак булган кош; *русчасы:* **пищуха**

**ЧЫЕЛДЫ́КЧАЛАР** *и. күпл. зоол.* Чыелдыклар, кычыткан чыпчыклары һәм шуларга охшаш кошларны берләштерә торган семьялык; *русчасы:* **пищуховые**

**ЧЫЖ** *иярт.* 1) Берәр нәрсә зур тизлек белән хәрәкәт итеп, һаваны ярып узу рәвешен һәм шуннан барлыкка килгән тавышны белдерә; выж. *Сызгырып очкан пулялар әле анда, әле монда чыж да чыж суга чумалар.* Г.Кутуй

2) *к.* **чыж-пыж**. *Клара кухня якта нидер пешерә, чыж да чыж кыздыра.* А.Хәсәнов

**ЧЫЖ ИТҮ** *ф.* Чыжылдаган тавыш чыгару. *Учак бераз төтенләп торды, чи чыбык башларыннан, чыж да чыж иттереп, салам юанлыгы гына төтен җепләре аттырды.* Г. Бәширов. *Йорт чатында яныма, чыж итеп, машина килеп туктады.* Н. Гыйматдинова

**ЧЫЖЛАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **чыжлау**. *Мәхмүтнең армиягә китү хәбәрен ишеткәч, Нурмигөл, бик якын кешесен озатырга җыенгандай, ашыгып, табасында карабодай коймаклары чыжлатырга тотынды.* Ф.Яруллин. *Нурулла һич өнәми яшьләрнең шушы шөгылен: элек бит, мал суелса, табада чыжлатып сызык куыралар, үпкә-бавыр, йөрәгеннән тутырма тутыралар иде.* Т.Гарипова

2) Чыжлаган тавыш чыгарып сугу. *Бабай, зәһәр тал чыбыгы белән чыжлатып, безне тәртипкә утырта иде.* Ә.Еники. *Күп чыжлатты ул шаһзадәнең аркасында сыек чыбыкны.* М.Әмирханов

**Чыжлатып алу** Бер тапкыр яки аз гына чыжлату. *Ул кулына озын чыбык тотып кердә. Башта, яшен уты уйнагандай, аны берничә кат чыжлатып ала.* С.Поварисов. *Чәй янына коймак та чыжлатып алгач, бөтенләй шаккатты.* Н.Гыйматдинова

**Чыжлатып җибәрү** Чыжлатырга тотыну. *Хисами моңарчы да эчкән иде, шуңа күрә бу эчкәне аның кыюлыгын кызган мунча ташыдай чыжлатып җибәрде, һәм егетнең бердән теле ачылды.* Г.Минский

**Чыжлатып йөрү** Һәрвакыт чыжлату. *Барысының да игътибары миндә, Рәисә ханым гына учак тирәсендә таба чыжлатып йөри.* Т.Әйди

**Чыжлатып карау** Сынау-тикшерү максаты белән чыжлату. *Мин, курайны авызыма кабып, үзем дә куык кебек өрелеп, чыжлатып карыйм.* Н.Дәүли

**Чыжлатып кую** Кинәт кенә бер тапкыр чыжлату

**Чыжлатып тору** Гел чыжлату, хәзерге вакытта чыжлату

**Чыжлатып яту** *сөйл. к.* **чыжлатып тору**

**ЧЫЖЛА́У** *ф.* Кызган май, бөркелеп чыккан пар, һаваны ярып узган чыбык һ.б.ш. сузып әйтелгән [ч] яки [ж] авазын хәтерләткән саңгырау тавыш чыгару. *Утлы күмерләр чәчрәп суга төшәләр дә чыжлап сүнәләр.* А.Тимергалин. *Чыбыркы чыжлады.* Г.Морат. *Тагын балталар шакылдады, ышкылар чыжлады, мүк кагучыларның имән чөйләргә китереп суккан тукмаклары такылдады.* Р.Газиз

**Чыжлап алу** Аз гына чыжлау. *Кызган мич ташыдай кинәт чыжлап алган Нәсыйх бу мизгелдә инде көлемсерәп бармак янаса да, Хәйдәр әле озак кына вакыт тын утырды.* В.Имамов

**Чыжлап җибәрү** Кинәт чыжларга тотыну

**Чыжлап кую** Бер тапкыр чыжлау

**Чыжлап тору** Даими чыжлау, туктаусыз чыжлау; хәзер, әле чыжлау хәлендә булу

**Чыжлап узу** Узышлый чыжлау. *Кинәт артымда нәрсәдер чыжлап узды, ул да булмый, өстемне нәрсәдер юешләп үтте – кемнеңдер корбанын суйдылар.* М.Кәбиров

**Чыжлый башлау** Чыжларга тотыну. *Утлы күмер өстенә эләккәч, майлы табага да тел иңә, чыжлый башлый.* А.Хәсәнов. *Гөлт итеп уты кабынды, газ плитәсендә чәйләре кайный, табалары чыжлый башлады.* Т.Әйди

**ЧЫ́Ж-ПЫЖ** *иярт.* Кат-кат, төрлечә чыжылдау тавышын белдерә. *Экранда әллә нәрсә чыж-пыж килде.* Г.Исхакый. *Без тулай торактагы бүлмәдәшем Маша белән сазаннарны чыж-пыж майлы табада кыздырабыз да өчәүләшеп ашыйбыз.* Н.Гыйматдинова

**ЧЫЖТ** *иярт.* Берәр тапкыр чыжлап куйган өзек авазны белдерә

**ЧЫ́ЖТ ИТҮ** *ф.* Кисәк сызгырган, чыжлаган тавыш чыгарып алу. *Шул вакытта пәһлеван Җайтабаровның сукыр эчәгесен чыжт иттереп кисеп алды да лач иттереп идәнгә ыргытты.* Г.Афзал. *Мырауша аквариумнан идәнгә сикерде дә, башын артка борган килеш, тычканнан күзен алмыйча, почмакка барып җитте, алгы аягы белән калайны чыжт итеп ярыктан читкә шудырды.* Ф. Садриев

**ЧЫ́ЖТ-ЧЫЖТ** *иярт.* Кабат-кабат, өзек-өзек чыжлау тавышын һәм рәвешен белдерә. *Чыжт-чыжт пычак кайрау*

**ЧЫ́ЖТ-ЧЫЖТ ИТҮ** *ф.* Кабат-кабат чыжлаган, өзек-өзек сызгыруга якын авазлар чыгару

**ЧЫ́Ж-ЧЫЖ** *иярт. к.* **чыж-пыж**. *Самавыр чыж-чыж кайный, кунакка дип коймак пешә иде.* Г.Исхакый. *Чыж-чыж килә пычкы!* Р.Фәйзуллин

**ЧЫЖЫЛДАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **чыжылдау**. *Сания сумкасын чыжылдатып япты.* Ф.Садриев. *Черек бәрәңге күмәчен табадагы каймакка чыжылдатып пешерсәң – дөньядагы бөтен ризыкларың бер якта торсын.* М.Мәһдиев. *Ләкин моның белән генә эше бетми әле: Әслах аларны табага сала да чыжылдата-чыжылдата кыздырырга тотына.* В.Имамов

2) *күч.* Берәр сыгылмалы нәрсә белән сугу, кору. *Маңгаена ак кулъяулык элгән төксе кыяфәтле ир, уңлы-суллы чыжылдатып, атны камчылады.* В.Имамов. *Сырт буйлап чыжылдату*

**Чыжылдатып алу** Аз гына яки бер тапкыр чыжылдату

**Чыжылдатып җибәрү** Чыжылдатырга тотыну. *Һаҗәр керә-керешли үк аңа дилбегә белән чыжылдатып җибәрде.*Ф.Садриев

**Чыжылдатып тору** Гел чыжылдату; хәзер, әле чыжылдату

**ЧЫЖЫЛДА́У** *ф. к.* **чыжлау**. *Менә каен төбен тоташ ут алды, аннан чыжылдаган, сызгырган тавышлар ишетелде, очкыннар чәчрәтеп, камчы айкагандай, учак эченнән еланнарның я койрыклары, я башлары атылып чыкалады.* Г.Бәширов

**Чыжылдап алу** Бераз гына, билгеле бер вакытта гына чыжылдау. *Кузгалып киткәндә тәгәрмәчләрнең усал чыжылдап алуы шефның гаять ачуланып, гарьләнеп китүенә ишарәле иде.* Д.Гыйсметдин

**ЧЫЖЫМ** *и.* Ике багана арасына сузылган тимерчыбык яки бау. *Урамнарның ике ягыннан да баганалар тезелешкән. Мирвәли бик бәләкәй чагында, «чыжым баганалары» дип йөртәләр иде аларны...* А.Гыйләҗев

◊ **Чыжым баганасы кебек (хәтле)** Ябык һәм озын буйлы, колгасар. *Трибунага чыжым баганасы хәтле бер ират күтәрелде.* З.Мәхмүди

**ЧЫЖЫМЛА́У** *ф. сөйл.* Үзенә бертөрле сызгыргандай тавыш белән чыжлап-чыжлап тору (телеграф чыбыклары тур.) *Чыжымлаган телеграмм баганасы буйларыннан кайткан да үземнең колагымны тарткан идем.* Г.Толымбай

**Чыжымлап тору** Гел чыжымлау; берникадәр вакыт чыжымлау

**ЧЫЙ** *и. диал.* Очлы әйбер белән тырнап ясалган сызык. *Чый ясау*

**ЧЫЙГЫЧ** *и. махс.* Балта эшендә: сызгы, сызгыч; *русчасы*: **чертилка**

**ЧЫК** I *и.* Җәй көнендә кич-иртән дымлы һава салкынаюдан үсемлекләр, туфрак һәм төрле предметлар өстенә куна торган су тамчылары. *Юл буендагы үләннәрдә салкын чык җемелди.* А.Тимергалин. *Болынлыкка һәркөн кичтән мул итеп чык төшә.* А.Хәсәнов

◊ **Чык белән** Иртә таңнан, иртәнге чык кибеп өлгермәс борын. *Әти белән Салих җизни көн беленә башлауга иртәнге чык белән беркавым чабалар да колхоз эшенә – клевер җыярга китәләр.* Р.Мөхәммәдиев. *Урманнарга барып, иртәнге чык белән, агач арасыннан кояш чыкканын күзәтер идем.* Безнең гәҗит.

**Чык яру** Чык төшкән чирәм буйлап бару. *Габделәхәтнең чык ерып барган чабаталары әнә шул куе үлән эчендә лаштыр-лоштыр килә.* Т.Нурмөхәммәтов. *– Чык ерып, бакча буйлап сандугач эзләп йөрим, ди! – диде кыз тавышы.* Н.Кәримова

**ЧЫК** II *иярт.* Гадәттә, металлны металлга, ташка яки башка бер каты нәрсәгә җиңелчә бәргәндә барлыкка килгән авазны белдерә

**ЧЫКЛЫ** с. Чык төшкән. *Алар, юл кырыендагы кичәге яңгыр шәбәрткән чыклы үләнне ярып, янәшә бара башладылар.* А. Гыйләҗев. *Синең өчен, бәлки, чыклы иртә, Бәлки, шыксыз төн мин.* Г.Морат

**ЧЫКЛЫ́ УТ** *и. бот. к.* **чыклы үлән**

**ЧЫКЛЫ́ ҮЛӘН** *и. бот.* Чыклыүләнчәләр семьялыгыннан яфраклары читендәге һәм өстендәге бизсыман төкчәләре ярдәмендә лайлалы сыекча бүлеп чыгарып, бөҗәкләрне аулый торган бер яки икееллык үләнчел үсемлек; чыклы ут; *русчасы:* **росянка**. *Чыклы үлән яфракларының бизләре бүлеп чыгарган сыекча органик матдәләрне эретә.* Робинзон эзләреннән

**ЧЫ́К-ЧЫК** *иярт.* Гадәттә, металлны металлга, ташка яки башка бер каты нәрсәгә бәргәндә барлыкка килгән авазларны белдерә. *Тотышның калканына берьюлы ике ук килеп тиде; тиде дә чык-чык итеп читкә китте.* Н.Фәттах

**ЧЫКЫЙЛЫ́К ҮЛӘНЕ** *и. диал.* Явымлы елларда уйсурак җирләрне каплап ала торган, ачык яшел төстәге, вак яфраклы чүп үлән; шеш үләне, үрдәк үләне

**ЧЫКЫЛДАГАН** *с. сөйл.* Нәкъ, үзе, нәкъ үзе; чын; чеп-чи. *Чыкылдаган йөз кырык өч меңне чыгарып салырга кирәк бит.* К.Тинчурин

**ЧЫКЫЛДА́У** *ф.* 1) Металл металлга, ташка һ.б.ш. каты предметларга бәрелгәндә саңгырау тавыш барлыкка китерү. *Карар укылып беткәч, алтатар чыкылдаганы ишетелә.* Р.Батулла

2) *к.* **чыкырдау** (*2 мәгъ.*). *Агачлар өстеннән әле йокламаган чәүкәләр чыкылдап очып үтәләр, гүя алар егетне сәламлиләр.* Р.Кәрами

◊ **Чыкылдап торган** 1) *к.* **чыкылдаган**. *Кызык бит: чыкылдап торган авыл егете, әмма колхозны танымаган, авыл җитәкчеләренә баш бирмәгән.* М.Шабаев. *Ә бит аларның байтагы – чыкылдап торган татар авылы малайлары...* Р. Фәйзуллин; 2) Таза, нык. *Хуҗабикәнең йорты яңа, шәп, чыкылдап торган нарат бүрәнәләрдән салынган.* Г.Гомәр; 3) Өр-яңа яки чиста итеп юылган һәм пөхтә итеп каралган. *Чыкылдап торган ак якалы күлмәк.* М.Галиев

**Чыкылдап алу** *к.* **чыкылдап кую**

**Чыкылдап кую** Бер тапкыр чыкылдау. *Сәйфетдин капчыкны пулемёт өстенә куйганда, аның эчендәге кыңгырау теле чыкылдап куйды.* З.Зәйнуллин. *Сәет кире китәргә дә уйлаган иде, кинәт эчке яктан ишек биге чыкылдап куйды.* Г.Гыйльманов

**Чыкылдап тору** Туктаусыз чыкылдау; әле хәзер чыкылдау

**ЧЫКЫРДАГАН** *с. сөйл. к.* **чыкылдаган**. *[Фәйзи] чыкырдаган меньшевиклар казанында кайный.* Ш.Камал

**ЧЫКЫРДА́У** *ф.* 1) **к. чыкылдау** (*1 мәгъ.*). *Шакырдаган-чыкырдаган тавышлар ишетелде, урам төтенгә күмелде.* А.Гыймадиев

2) Еш һәм өзек-өзек кыска тавышлар чыгарып кычкыру (гадәттә саесканнар тур.)

◊ **Чыкырдап торган** *к.* **чыкылдап торган**

**Чыкырдап кую** Бер тапкыр чыкырдау. *Бер үк вакытта кухняда да аппарат чыкырдап куйды.* И.Хуҗин

**ЧЫКЫРДАШУ** *ф. к.* **чыкырдау**. *Нишләптер аның хәтерендә имән ботагында чыкырдашып утырган ике кошчык калган.* А.Нәҗми. *Саесканнар чыкырдый*

**ЧЫЛАНДЫРУ** *ф. йокл. юн. сөйл. к.* **чылату**. *Аннары Васия, озын толымнарын башына урап, аларны чыландырмыйча коена.* М.Хуҗин. *Резидә Хәсәнованың «Ана бәйрәме» шигырен сәнгатьле итеп сөйләве, Айрат Хәбибуллинның зур осталык белән «Сугышка китәм» җырын башкаруы күпләрнең күңелен нечкәртеп, күзләрен чыландырды.* Авыл офыклары

**Чыландыра төшү** Бераз чыландыру

**Чыландырып кую** Тиз генә яки алдан чыландыру

**ЧЫЛАНУ** *ф.* 1) Дым, су тәэсирендә юешләнү. *Арыш ерып кайткан чакта кичке ызаннан, күлмәген сыгардай булып Дженни чыланды.* А.Хәлим

2) Каплап алыну, юешләнү (күз яшьләре белән). *Уйларга да өлгермәде мискин гашыйк, Кайнар яшькә ике күзе чыланды да!* Г.Тукай. *Хәерчелеккә баткан, күз яшьләренә чыланган, аһ-зар белән тулган ил елый.* А.Алиш. *Фаягөл карчыкның берән-сәрән генә калган керфекләре яшькә чыланды.* А.Әхмәтгалиева

**Чылана бару** Торган саен чылану. *Чумырган саен, чокыр тирәнәйгән саен, кар авырая, чылана бара.* М.Маликова

**Чылана башлау** Чыланырга тотыну. *Күзләрем яшәреп, яңак буйларым чылана башлады.* Г. Ибраһимов

**Чылана тору** Һаман чылану. *Никадәр корытып сөртсә дә, керфекләр һаман чылана торды.* Р.Төхфәтуллин

**Чылана төшү** Бераз чылану. *Канәгать кулында калган балыкларны су өстенә сипте дә урыны-урыны белән чылана төшкән күлмәген юеш кулы белән рәтләде.* А.Хәлим

**Чыланып алу** Бераз чылану. *Алсуга карап, егетләрнең дә күзләре чыланып ала, ләкин алар күз яшьләрен яшерәләр.* И.Хуҗин

**Чыланып бетү** Тәмам чылану. *Битләре, борын буйлары, бармаклары күз яшенә чыланып бетте.* Г.Ибраһимов. *Сугышчылар тәмам хәлдән тайдылар, суга чыланып беттеләр, җил үзәккә үтеп исә.* Г.Әпсәләмов

**ЧЫЛАТУ** *ф.* 1) Юешләү; су тидерү, су сеңдерү. *Мәхмүт тә, су эчеп, битен чылатып, үз эше белән китә.* А.Гадел. *Бары тик ара-тирә салкын тау сулары белән бит-кулларын юа, авызын чылата.* А.Нәҗми

2) Каплап алу, юешләү (күз яшьләре). *Яктылыкның тоныкдымын җыйган Керфегемне яшькә чылатма.* А.Хәлим

3) Тиешле үзлекләр бирү өчен, суга батырып тоту. *Җәйгә чыксаң, баса җебетергә, җитен чылатырга тилмереп торасың: су табып булмый.* И. Гази

4) *күч.* Бала туу уңаеннан бәйрәм оештыру, мәҗлес ясау. *Иптәшләр, дусиш белән малайның тәпиен чылатып алырга да кирәк.* А.Гыйләҗев

**Чылата башлау** Чылатырга тотыну. *Балҗан инде кимсенә, мендәрне шыпырт кына күз яшьләре белән чылата башлаганда гына, кыяр-кыймас кочаклап алды.* Т.Әйди

**Чылата төшү** Бераз чылату; тагын да чылату

**Чылатып алу** Тиз арада, аз гына, тиз генә чылату. *Йолка кызлар, каз йолкалар, бармагың чылатып ал!* А.Хәлим

**Чылатып бетерү** Бик нык, баштанаяк, барысын да чылату. *Ул, үрелеп, малайның керфекләрен, йөз-битләрен чылатып бетергән күз яшьләрен сыпыргандай итте.* Г.Гыйльманов. *Гөлназның да күз яшьләре ага да ага, бите буйлап агып төшеп, муенын, күкрәкләрен чылатып бетерде.* И.Нәбиуллина

**Чылатып кую** Алдан яки кинәт кенә чылату; билгеле вакыт аралыгын чылатып үткәрү. *Бигрәк тә көзге яңгырларда, кыеклап сипкән яңгыр тәрәзәсез төньяк стенаны урын-турын чылатып куйган булса, йорт моңлы була.* М.Мәһдиев

**Чылатып чыгу** Һәрберсен берәмберәм чылату. *Күрше кызы Алмазиянең (без бер сыйныфта укыйбыз) сәгать ничәдә йокларга ятканын да, иртә белән нәрсә ашаганын да, сөтле аш яратмаганын да, зәңгәр чәчәк төшкән күлмәк өчен апасы белән сатулашып, төн буе мендәр чылатып чыкканлыгын да, аның гөлләр үстерергә яратанлыгын, өендәге роза гөле сулгач, тамактан калганын да беләидем.* З.Хөснияр

**Чылатып тору** Әледән-әле чылату; әле, хәзер чылату. *Санинструктор Михаил Калапаев рөхсәт итми, иреннәрен генә чылатып торырга куша.* З.Мәхмүди

**ЧЫЛАШТЫРУ** *и. лингв.* Башлыча [ц], сирәгрәк [с] урынына [ч] авазы белән сөйләү. *Мишәр диалектының темников, ләмбрә (Мордовия), кузнецк (Пенза өлкәсе), хвалын, мәләкәс, карсун (Ульянов өлкәсе), подберезенск-керәшен, чистай-керәшен (Татарстан), эстәрлетамак (Башкортстан), шарлык (Оренбург өлкәсе), куршин (Тамбов өлкәсе), волгоград (Әстерхан һәм Волгоград өлкәләре, Ставрополь крае) сөйләшләренә чылаштыру хас.* Татар сөйләшләре

**ЧЫЛБЫР** *и.* **1.** 1) Төрле формалы металл боҗраларны бер-берсенә кидереп ясалган бау. *Икенче тапкыр качып тотылгач, аларны башта бер каталажкага ябып, качмасыннар дип, кулаякларыннан стенадагы чылбырларга*

*беркетеп куйдылар.* Г.Әпсәләмов. *Аннары, гаражга төшеп, Газинур муенчак, чылбыр алып менде.* А.Хәсәнов

2) Кыйммәтле металлардан шундый бауга охшатып ясалган бизәнү әйбере. *Чәчен ирләрчә кыска итеп кистергән, өстенә бик тар күлмәк кигән, муенына нечкә алтын чылбыр белән түгәрәк кулон таккан, ялангач беләгенә төймә хәтле генә алтын сәгать бәйләгән җете кызыл иренле бер кыз белән Мансур баскычтан менеп килә иде.* Г.Әпсәләмов

3) *этн.* Гадәттә көмештән, ташлар яки тәңкәләр белән бизәп ясалган изү каптырмасы яки муенга кия торган бизәнү әйбере

4) *сөйл.* Богау, зынҗыр. *Бунның аягына тимердән ясалган чылбыр кигезгәннәр.* Г.Исхакый. *Урманга чыгып югалмасын, мина-мазарга басып шартлый күрмәсен дип, авылдашлары Макриддина түтәйне бер землянкага ябып, чылбыр белән бәйләп тоталар.* А.Хәсәнов

5) *күч.* Ирекне, азатлыкны буып торган нәрсә; зынҗыр. *Тоткынлык чылбырыннан ычкына алу*

6) *күч.* Нәрсәнең дә булса бер-бер артлы тезелеп, сузылып киткән тәркеме. *Иңкүлектән биек ур өстенә чылбыр булып тезелгән дружина калкып чыкты.* В.Имамов. *Чылбыр булып тезелгән кыр үрдәкләрен дә күңел күзем белән беренче тапкыр күрәм ләбаса.* А.Әхмәтгалиева

7) *күч.* Бер-бер артлы эзлекле тезелеп барган уй-фикерләр, вакыйгалар теземе. *Туләнгән гомерләрдән чылбыр ялгана – Мәңгелек чылбыры.* М.Шабаев. *Уяу чагында кеше бик томанлы гына күзаллаган нәрсәләр аның төшендә ныклы логикага нигезләнгән бер чылбыр булып тезелергә мөмкин.* А.Тимергалин

8) *махс.* Берничә элементтан ялгап ясалган юл яки сызык тәшкил иткән җайланма һәм аның схемасы, планы. *Шул ук елны Куйбышев – Мәскәү электр тапшыру линиясенең беренче чылбыры эшли башлады.* СССР тарихы. *Электр чылбыры*

**2.** *с. мәгъ.* 1) Металл боҗралардан ясалган баудан гыйбарәт; шундый формада, шуңа охшатып ясалган. *Ничә карама, муенында чылбыр галстук.* А.Хәсәнов. *Т-34 танкысы, чит җирнең соргылт-комсу туфрагын чылбыр табаны белән изеп, төтен-сөрем ерып, зур тизлек белән бара иде.* М.Маликова

2) *мат.* Санаучысына һәм ваклаучысына чиксез рәвештә вакланмалар кушыла торган. *[Югарыда китерелгән рәвештәге] вакланма өзлексез яки чылбыр вакланма дип атала.* Алгебра

3) *физ., хим.* Берәр атомның яки төшнең реакциясе эзлекле рәвештә бик күп сандагы атомнарның, молекулаларның яки төшләрнең реакциясен китереп чыгара торган. *Берәр техник ялгышлык аркасында гына да чылбыр реакциясе башланса?..* А.Хәсәнов

◊ **Чылбырдан ычкыну** *к.* **бәйдән ычкыну** (*1 мәгъ.*). *[Рим:] Мин хәзер – чылбырдан ычкынган юлбарыс!* И.Юзеев. *Шәех үзен озак көттермәде, чылбырдан ычкынган шикелле атылып чыкты да тупка каршы ыргылырга җыенды.* Ә.Мушинский

**ЧЫЛБЫРЛАТУ** *ф. йөкл. юн. Чылбыр белән бәйләргә ирек бирү*

**ЧЫЛБЫРЛАУ** *ф.* 1) Чылбыр белән бәйләү. *Закир абый Рексны чылбырлады да, Сарбайны оядан тартып чыгарып, малайларга атты.* И.Гази. *Ике ир, аны югарырак сөйрәп, тимер казыкка чылбырлап йозакладылар да, салмак кына атлап, киң елга борынында кояшка карап утырган кечкенә ызбага карап юнәлделәр.* З.Мурсиев

2) *күч.* Иркенләп эш итү мөмкинлеген бетерү, ирексезләү. *Әмма озакка бармады бу сызлау, барча вөҗүден ду китерде, уйларын үзенә чылбырлады.* Х.Камал

**Чылбырлап кую** Тиз генә яки алдан чылбырлау. *Пирамиданың фасад баскычына ике көймә чылбырлап куелган.* А.Тимергалин. *Кайчакларда, төннәрен шәһәр урамнарында йөри-йөри, мин яр буйларына килеп чыгам, анда чылбырлап куелган көймәләр күрәм.* М.Вәлиев

**Чылбырлап тору** Гел, һәрвакыт чылбырлау; әле хәзер чылбырлау

**ЧЫЛБЫРЛЫ** *с.* 1) Чылбыры булган, чылбыр тагылган. *Түш кесәсеннән чылбырлы сәгатен алып карый-карый йөренә.* И.Юзеев

2) Чылбыр ярдәмендә эшли торган. *Шулай аптырашып торганда, артларыннан чылбырлы зур трактор куып тотты.* Г. Әдһәмова

3) *махс.* Алдагысы үзеннән соңгысын китереп чыгара торган, эзлекле барган. *Чылбырлы рефлекс. Чылбырлы реакция*

**ЧЫЛГЫЙ** *и.* **1**. 1) Кошларның иң нык, иң калын һәм иң зур каурыйларыннан булган җилпенү каурые. *Кошның чылгый каурыйлары аклы-каралы*

2) *иск.* Озын киемнең чабуы. *Чапан чылгые*

3) Мыекның бөтереп куйган очы. *Кешеләр, чылгый очындагы ярым айга, озынча төннекләргә бармаклары белән төртеп күрсәтә-күрсәтә, пышылдашып, үзара гөр киләләр. Н.Фәттах*

4) Очы бөдрәләнеп килгән чәч тотамы

**2.** *с. мәгъ.* Озаеп, салынып, очлаеп торган. *Шулай чарасыз пошманда торганда, Исхакның күзенә, арык атын җай гына атлатып килүче, кабык арбалы, чылгый мыеклы бер агай чалынды.* А.Гыйләҗев

**ЧЫЛГЫЙЛАНУ** *ф.* Очлары чылгый ясап очлаеп тору. *Аның ялтырап торган чем кара куе чәче, бераз кысыла төшкән ялтыр кара күзләре, бераз кытайны хәтерләтә торган киң карасу йөзе, җәенкерәк борыны, ике якка чылгыйланып килгән кара мыегы күренү белән, һәммә кешенең күзен тарттылар.* Г.Ибраһимов. *Калын, таза муенлы булганга, җиту сакалы, чылгыйланып торган кырпак мыегы бик килешеп тора үзенә.* Ә.Галиев

**ЧЫЛДЫРА́У** *ф. сөйл. к.* **чылтырау** (*2 мәгъ.*). *Ләкин кыз берни дә әйтми, бары тик чылдырап көлә генә...* М.Мәһдиев

**ЧЫЛДЫРДА́У** *ф. сөйл. к.* **чылтырау** (*2 мәгъ.*). *Соң гына кайтып кергән улының хәлен ана тиз аңлады: өйалдында дагалы итек тавышлары кичәгедән катырак чыкты, гимнастёркадагы орден-медальләр кичәгедән ныграк чылдырады, уфылдаган, аһылдаган тавышлар чыкты.* М.Мәһдиев

**ЧЫЛДЫРТ** *ияրт. к.* **чылтырт**. *Суык язмышка үпкә хисләре күңелгә тулды, һәм алар, бозлар белән бергә, кәйлә ярдәмендә кителә төшә: – Чылдырт, чылдырт, чылдырт...* Ә.Баян

**ЧЫЛДЫ́Р-ЧЫЛДЫР** *ияրт. к.* **чылтыр-чылтыр**. *Чылдыр-чылдыр су тавышы – Гүя язгы кар суы.* К.Насыйри. *Чылдыр-чылдыр килә богау чыңы, шундый авыр куллар, аяклар.* Г.Латыйп. *Үсеп җиткән ак күлмәкле кыз бала чылдыр-чылдыр су ала.* Р.Мингалим

**ЧЫЛТ** *ияրт.* Вак металл әйбер бәрелгәндә, суга балык чумганда барлыкка килгән h.б.ш. өзек авазны белдерә. *Күлнең кырыйларында сикерә-сикерә уйный торган балыклар да үзләреннән соң түм-түгәрәк сызык калдырсалар да, ул сызык киңәеп-зураеп югалганчы китсә дә, аларның да көмеш аркалары кояшка каршы ялтырап сәлам*

*бирүләре күренсә дә, аларның да суга чылт итүләре дә шул тынлыкта бата иде*. Г.Исхакый. *Шулай диде дә, мине тәмам аптырашта калдырып, чылт итеп трубканы куйды бу.* М.Маликова

**ЧЫ́ЛТ-ЧЫЛТ** *иярт.* 1) Вак металл әйберләр бәрелгәндә чыккан һ.б.ш. авазларны белдерә

2) Еш-еш күзне ачып йому рәвешен белдерә; мелт-мелт. *Күзләрен чылт-чылт йомып, түшәмгә карый-карый Әлтафи сөйли.* М.Мәһдиев. *Бу минутта аның күзләре дымланып, керфекләре чылт-чылт йомыла башлады*. Ф.Яруллин

**ЧЫЛТЫР** *иярт.* Металл, фарфор, пыяла һ.б.ш. әйберләр бер-беренә бәрелгәндә барлыкка килгән нечкә яңгыравык тавышны белдерә. *Башта без, чылтыр да чылтыр китереп, төнге суыкта ат эзләренә каткан пыяладай юка бозларны ватып йөрдек.* Г.Бәширов

**ЧЫЛТЫРАВЫК** *с.* Чылтыраган тавыш чыгара торган. *Зәки кебек, чылтыравык тәтиләр таккан түшен киереп йөрергә яратмый.* Л.Закир. *Аның чылтыравык тавышы бая яңгыраган моңлы җыр булып тоелды.* Мәйдан

**ЧЫЛТЫРАТУ** *ф. йөкл. юн. к.* **чылтырау.** *Равил велосипедының кыңгыравын чылтыратты.* В.Нуруллин. *Шундук, чулпыларын чылтыратып, апай да чыгып җитте.* Г.Бәширов

**Чылтыратып алу** Тиз генә, аз гына чылтырату. *[Ирек:] Бабай, мин Ләйсәнгә чылтыратып алыйм әле.* Г.Тарханова. *Нәҗип, өйгә кайтыр алдыннан, өенә чылтыратып ала.* Т.Галиуллин

**Чылтыратып җибәрү** Кинәт чылтырату. *Шул минутта тышта капка төбендә бик каты: «Гөрссс!.. Гөрссс!..» – иткән тавыш бу кечкенә өйнең тәрәзәләрен чылтыратып җибәрде*. Г.Ибраһимов

**Чылтыратып йөрү** Гел чылтырату. *Сала малайларының күзен ут итеп, чирәмле тигез урамнарда каз бәпкәләре арасыннан кыңгырау чылтыратып йөрсен әле бер!* А.Гыйләҗев

**Чылтыратып карау** Сынау өчен чылтырату. *Уйлый торгач, ул тормышны белүче ахирәтенә чылтыратып карарга булды.* И.Хәйруллин

**Чылтыратып кую** Бер тапкыр чылтырату

**Чылтыратып тору** Даими яки әледән-әле чылтырату; хәзер чылтырату. *Ул баянга кушылып уйнаганда, Сәгыйдулла абзый кыңгырау чылтыратып тора – Фатих Кәримнең «Кыңгыраулы яшел гармун»ы искә төшә.* И.Юзеев

**ЧЫЛТЫРА́У** *ф.* 1) Су ташларга бәрелә-бәрелә акканда үзенчәлекле тавышлар чыгару, чылтыр-чылтыр итү. *Кояш кыздыра, кошлар сайрый, чишмәләр чылтырап ага.* А.Алиш. *Улаклардан, чылтырап, чишмә суы агып тора.* А.Хәсәнов

2) Металл, пыяла һ.б.ш. әйберләр бәрелгәндә яңгыравык нечкә тавыш барлыкка китерү. *Аның артыннан капканың биге чылтырап төште.* А.Тимергалин

3) Телефон, ишек кыңгыравы һ.б.ш. үзенчәлекле сигнал бирү. *Колакны ярып, кыңгырау чылтырады.* А.Әхмәтгалиева

4) *күч.* Аһәңле, матур яңгырау (музыка тавышы тур.)

**Чылтырап алу** Аз гына чылтырау

**Чылтырап китү** Кинәт кенә чылтырау. *Ул да булмады, дыр-р-р итеп капка бастырыгын шудырдылар, келәчылтырап китте, һәм Шәмсуннең каршында ук җилкәсенә кыска тун бөркәнгән Минәтнең иртәнге эңгергә төренгән түгәрәк йөзе пәйда булды.* А.Вергазов

**Чылтырап кую** Бер тапкыр чылтырау. *Шунда кисәк кенә ишек кыңгыравы чылтырап куйды.* В.Нуруллин

**Чылтырап тору** Әледән-әле чылтырау; озак вакыт чылтырау. *Телефон чылтырап торды.* Р.Харис

**Чылтырап яту** *сөйл.* Чылтырау процессында булу. *Менә шунда инде изге чишмә чылтырап ята.* Г.Каюмов

**ЧЫЛТЫРАУЛЫ** *с.* Чылтырый торган, чылтыравык. *Көндезге дүртләр тирәсе, ә чылтыраулы һәм ялтыраулы көн караңгылык һәм бозлар әсирлегенә бирешергә җыенмый әле.* Ә.Мушинский

**ЧЫЛТЫРДА́У** *ф. сөйл. к.* **чылтырау**. *Ләкин Мәрьям түзә алмады, Зыя дустлык кыяфәте белән картка якын ук килгән секундта, баягы ишек янында теге шәүлә заһир булып, ачы рәвештә кулбавы чылтырдады да, «Юк, булмый, өмит бетте!» дигән мәгънәне аңлатырлык кәйфияттә, яулык селкенгәне күренде...* Г. Ибраһимов

**ЧЫЛТЫРТ** *иярт.* Металл, пыяла һ.б.ш. әйберләр бер-берсенә яки ниндидер каты нәрсәгә бер тапкыр бәрелгәндә чыккан өзек яңгыравык тавышны белдерә

**ЧЫЛТЫ́РТ ИТҮ** *ф.* Кисәк чылтырап кую. *Чыңгылдады хәтер чоңгылында, чылтырт итте тагын әллә ни...* З.Мансуров. *Тыштан стенага бәрелгән пулялар чылтырт итеп коелып төшә.* Х.Камалов

**ЧЫЛТЫ́Р-ЧЫЛТЫР** *иярт.* **1.** 1) Чишмә, кечкенә елга ташларга бәрелеп акканда барлыкка килгән тавышны белдерә. *Тау астында салкын чишмә Чылтыр-чылтыр агадыр*. Җыр

2) Металл, пыяла кебек каты нәрсәләр бер-берсенә кат-кат бәрелгәндә барлыкка килгән тавышны белдерә

3) Берәр электроник җайланма, телефон, ишек кыңгыравы сигнал биргәндә чыккан тавышларны белдерә. *Чылтыр-чылтыр ... звонок, Хәзер пәрдә ачыла*. М.Җәлил

**2**. *рәв. мәгъ*. Ташларга бәрелүдән характерлы тавыш чыгарып, чылтырап. *Авылның түбән очындагы чишмәнең әргән уйнаган шикелле чылтыр-чылтыр агуы, этләрнең ялкау гына өреп алулары, кайдадыр Гафиятулла бабайлар ягында сыздырган гармун көенә кемнәрнеңдер кушылып җырлап җибәрүләре ишетелә.* Г.Әпсәләмов. *Бакчада гаҗәеп агачлар, гаҗәеп гөлләр үсә, түгәрәк күлләр елтырап ята, чылтыр-чылтыр чишмәләр агып тора*. Ә.Еники

**ЧЫЛТЫ́Р-ЧЫЛТЫР ИТҮ** *ф.* Чылтыраган тавышлар чыгару. *Ашка килгән егетләр чәкчәкне авыз иткәннән соң, һәркем хәлле хәленчә, чәкчәк котлап, табынга алдан ук куелган җиз подноска яисә зур тарелкага, чылтыр-чылтыр итеп, көмеш тәңкәләр салалар.* Т.Гыйззәт

**ЧЫМЫРДАТУ** *ф. йөкл. юн. к.* **чымырдау**. *Тәнне чымырдатып, йөрәкне сикертеп, ачы хатирәләр бер-бер артлы алышындылар: беренче зур кайгы анасының үлүе булды.* А.Алиш. *Умрау сөягемә типте йөрәк, суык чымырдатты канымны*. Р.Харис

**Чымырдата башлау** Чымырдатырга тотыну. *Тәнне чымырдата башлады*

**Чымырдатып алу** Бераз чымырдату. *Бу саф һава Хәлимә туташны бик тиз кочаклап алганга, электрик куйган кебек, аның тәннәрен чымырдатып алды.* Г.Исхакый. *Бүтән планеталарга барып ирешкәч, Җир тавышы да шундый якын, үз, йөрәкне чымырдатып ала торган булыр.* Ш.Галиев

**Чымырдатып җибәрү** *к.* **чымырдата башлау.** *Инде Разиләсез дә калыйммы, дигән уй тәннәремне тагын да чымырдатып җибәрде.* Р.Рахман

**Чымырдатып кую** Кинәт кенә чымырдату. *Әхмәтнең тавышы бик тә*

*моңлы, аның җыры тәннәрне чымырдатып куя иде.* Г.Бәширов

**Чымырдатып тору** Әледән-әле, гел чымырдату; хәзер, әле чымырдату

**ЧЫМЫРДА́У** *ф.* 1) Әче камыр, кайбер шәраблар һ.б.ш. газ чыгарып, сузып әйтелгән [ш] авазын хәтерләтә торган тавыш барлыкка китерү. *Берәр стакан гына әллә нинди чымырдап, күбекләнеп торган су эчердeләр.* М.Галәү. *Учыңда кош оясы кебек җайлы урнашкан касәдә салкын кымыз чымырдый.* М.Галиев

2) Тәндә җиңелчә генә өшетү, чәнчешү, тартышу, калтырау тойгысы барлыкка килү. *Бу тавыш Әхәтнең йөрәгенә барып бәрелгәч, тәне чымырдады...* А.Алиш

**Чымырдап кую** Кинәт кенә чымырдау. *Ул төн исенә төшкән чакларда әле хәзер дә тәннәре чымырдап куя Фәләхнең.* В.Нуруллин

**Чымырдап китү** Кинәт чымырдау. *Төсе әллә нидән булмаса да, нык, калын тукымадан тегелгән яңа пәлтәне күргәч, куанычымнан тыннарым кысылып, тәннәрем чымырдап китте.* В.Нуруллин. *Мөнирәнең тәне чымырдап китте.* Г.Әпсәләмов

**Чымырдап тору** Даими, гел чымырдау; хәзерге моментта чымырдау. *Шулвакыт минем аркамда суык чымырдап тора, вә мин ихтыярсыз, хәзер генә сүнеп, капкачы ябылган мич янында торып кына, бабай белән сөйләшә ала идем.* Г.Тукай. *Таһирның йөрәге җилкенеп, тәне чымырдап торды.* Г.Гыйльманов

**Чымырдый башлау** Чымырдарга тотыну. *Шул искә төшсә, әле дә тәннәрем чымырдый башлый.* Г.Гыйльманов

**ЧЫМЫРТКЫ** *и. диал.* 1) Ачыткы, оеткы. *Һәрнәрсәнең үз чымырткысы.* Әйтем

2) *куч.* Нәрсәнең дә булса башлангычы. *Дөнья чәчәктә, малайлар чымырткы хәлендә.* З.Мурсиев

**ЧЫМЫ́Р-ЧЫМЫР** *иярт.* 1) Сыек матдәләрнең әчеп утырган вакытта барлыкка китергән тавышны белдерә. *Квас чымыр-чымыр утыра*

2) Тәннең җиңелчә чәнчешү, өшетү рәвешен белдерә

**ЧЫМЫ́Р-ЧЫМЫР КИЛҮ** *ф.* 1) Күбекләнеп, кабарып, әкрен генә әчеп утыру. *Камыр чымыр-чымыр килә*

2) Тәндә еш-еш чәнчүләр тоелу, тәнне чәнчеп-чәнчеп алу. *Егетнең аркасын чуарлаган яра җөйләре чымыр-чымыр килде.* А.Гыйләҗев. *Аны тыңлаганда, Гөлҗиһанның тәннәре чымыр-чымыр килә, күзләре яшьләнә иде.* Ф.Бәйрәмова

**ЧЫМЫТКЫ** *и. диал.* 1) *к.* **чымырткы**

2) Квас. *Кояш кызуы сусатканга, сатучылар теземеннән аерылып, күбрәк кеше чымыткы сатучылар теземе янында буладыр.* Шура

**ЧЫН** *с. кыт.* **1.** 1) Чынбарлыктагыча булган, чынбарлыкка туры килгән, реаль. *Абыстайлар, буласы бүләкләр бар да чын, күз алдау түгел.* А.Гадел. *Минем туган Ватанымда... туган йортым ихатасында чын атым да, этем дә, чын песием дә бар...* А.Хәлим

2) *сөйл.* Дөрес, хакыйкатькә туры килгән, хак. *Чын сүз*

3) Ясалма булмаган, табигый. *Чын кытай ефәге!* А.Гыйләҗев. *Ну, чегәннәре безнекеләрдән мең тапкыр хәйләкәррәк икән! Үзебездә өч тиенгә сата торган ясалма күн курткаларын чын күн бәясеннән сатып алып кайттым.* Р.Шәрипова

4) Нәкъ үзе булган; тиешле таләпләргә җавап бирә торган. *Без чын дуслар идек.* А.Мансуров. *Мотор ипподромнарда тәрбияләп үстергән метис түгел, туган як болыннары тудырган, шунда үскән чын юртак иде.* А.Хәсәнов

5) Иң яхшы үрнәк, идеал булып торган. *Чын шигырьләргә бер чакта да пычрак кунмый, гайбәтче теле дә кисә алмый аларны!..* А.Гыйләҗев. *Чын галим – биологмы, физикмы яки математикмы ул – әйләнә-тирә дөньяның чиксезлегенә, дөньядагы тәртипнең искиткеч оешканлыгына, максатчанлыгына, анда мәгънәсез бер генә нәрсәнең дә булмавына торган саен ныграк ышана.* А.Тимергалин

**2.** *и. мәгъ.* 1) Чынбарлык, реальлек. *Безнең таулар – җырда зәңгәр, Кырым таулары чында зәңгәр.* Ш.Галиев. *Ике ак күбәләк кебек чәченә үреп куйган ак бантиклар, адым саен кузгалып торып, читтән карасаң, чында да ике дәү күбәләк сыман, кызның башына кунганнар да, нигәдер очып китәлми талпынып-талпынып алалар да кире куналар шикелле күренә.* В.Ильясов

2) Хакыйкать, хак, дөреслек. *Юл күрсәтә чынга, дөреслеккә?* К.Булатова. *Ә хәзер шуның әйткәннәре бары чынга килеп тора.* М.Яһудин. *Һәм сез өйрәткән тәгълиматны гына чынга исәплим.* М.Кәбиров

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Чынбарлыкта, реаль тормышта. *Чын булган хәл*

2) Чынлап, шаяртмыйча яки алдамыйча. *Чын әйтәмен, аппагым, Күз алдымнан бер дә китми Кыңгыр салган калфагың.* Җыр

**4.** *хәб. функ.* Хак, әйе, чынлап та шулай. *Агаем, мин сиңа кирәгрәк, дигән кебек тоелды көчекнең үз итеп тавыш бирүе, шул йомшак чинау, чын әгәр, буйсындырды да куйды картны.* М.Хуҗин

◊ **Чын ихлас белән** *к.* **чын күңелдән**. **Чын ихластан** *к.* **чын күңелдән**. *[Нәгыйм:] Чын ихластан партиягә керергә теләгем бар иде.* Ш. Камал. **Чын йөрәктән** *к.* **чын күңелдән**. **Чын күңелдән** Икейөзләнүсез; яхшы ният белән; эчкерсез рәвештә.*Остабикә белән икебез дә сезне бу саваплы гамәлегез – булачак никахыгыз белән чын күңелдән тәбрик итәбез.* Г.Бәширов. – *Борчылмагыз, абый, – диде стюардесса, аны чын күңелдән кызганып.* З.Мәхмүди. **Чын мәгънәсендә** Чыннан да, чынлап та. *Адәм баласын чын мәгънәсендә олы итә, бөек итә торган хисләр болар.* А.Хәсәнов. *Хәзер ул чын мәгънәсендә шәһәр зыялысына әверелгән: өстендә чем кара коверкот костюм, ап-ак күлмәк, кара җирлеккә түгәрәк зәңгәр төртке төшерелгән галстук таккан.* В.Нуруллин. **Чын ясау** Бик матур, пөхтә, купшы итеп. *Тикшерергә килүчеләр чын ясау булып киенгәннәр: өсләрендә яхшы тун, аякта һәйбәт күн итек, билләрендә билбау.* Г.Бәширов. *Ләкин бу инде хәзер клуб түгел, ә мәдәният йорты: ике катлы, таштан салынган, эче-тышы чын ясау итеп бизәлгән.* Р.Кәрами. **Чынга алу** Нindидер хәбәргә, мәгълүматка ышану, дөрес дип кабул итү. *Ул чагында мин чынга алмадым.* В.Имамов. *Айдар, аның сүзләрен чынга алып, кат-кат гафу үтенергә кереште.* И.Диндаров. **Чынга бору** Уйнап башланган эшне яки мәзәк сүзне җитдигә әйләндерү. **Чынга җибәрү** Ялган яки уйнап әйтелгән сүз яки хәбәргә җитди төс бирү, чынга бору. *Чын менә, гел-гел сине уйлыйм, тирә-юньдәге бөтен нәрсәдә сине «күрәм».* А.Әхмәтгалиева. **Чынга китү** Шаярып башлаган эш-гамәл җитди нәтиҗәләр чыгарлык формага күчү. *Энем, уен бетте, чынга китте.* Г.Каюмов

**ЧЫНАГАЧ** *и.* Өрәңге. *Мин, ни, [ишекне] чынагач сабагы кыстырып кына япкан булган идем дә, әнә бит нишләтә.* М.Әмир

**ЧЫНАЯК** *и.* **1.** 1) Чәй һәм кайбер башка эчемлекләр эчү өчен фарфор, фаянс һ.б.ш.дан ясалган, зур булмаган

тәлинкә һәм тоткалы касәдән гыйбарәт парлы әсбап. *Чәй чынаягы өч булыр, өчтән ары хуҗага көч булыр.* Мәкаль

2) Шундый әсбапның тоткалы тирән касәсе, чокыры. *Өстәлдә ярты савыт аракы, бер чәй чынаягы утыра иде.* Ш.Камал

3) Стеналарның, мичләрнең өслеген каплау өчен ялтыравык керамикадан гыйбарәт плитка

**2.** с. *мәгъ.* 1) Керамикадан ясалган, керамикадан гыйбарәт. *Чынаяк мичләр авылда еш очрыймы?* Гали Рәхим

2) Фарфор, фаянс яки керамикадан гыйбарәт. *Зәңгәрсу чынаяк кирпеч белән тышланган, җылы төннекләре җиздән, мич капкачларын сырлап-сырлап чуеннан койган...* А.Тимергалин

◊ **Чынаяк белән асты кебек** Һич юктан да сүзгә килешә, ачуланыша башлый торган кешеләр турында

**ЧЫНАЯКЛЫ** *с.* 1) Чынаягы булган. *– Бөтен кеше үз белгечлеге буенча эшләсә, кешелек дөньясы әллә кайчан шундый да үсеш дәрәҗәсенә ирешкән булыр иде инде, – дип көлде чынаяклы кыз, – минем, мәсәлән, бер белгечлегем дә юк.* Г.Бәйрәмова

2) *физ.* Берәр фарфор, фаянс яки керамик детале булган, шуның ярдәмендә эшли торган. *Чынаяк барометр*

**ЧЫНБАРЛЫК** *и.* 1) Берәр нәрсәнең реаль яшәве, булуы; реаль, чын булган нәрсә. *Төш күреп ятсам да, моның чынбарлык булмавын чамалый башладым кебек.* З.Мәхмүди

2) Кешеләрнең объектив яшәү шартлары, кешеләрне чолгап алган тирәлек, реаль тормыш. *Ләкин теләк белән чынбарлык – икесе ике нәрсә шул.* В.Нуруллин. *Бөтен чынбарлык, әйләнә-тирә мохит хәтер белән бүләкләнгән.* А.Нәҗми

**ЧЫНБАРЛЫКТА** *рәв. к.* **чынлыкта**. *Риваять чынбарлыкта булырга мөмкин...* Г.Гыйльманов

**ЧЫНЛАП** *рәв. сөйл.* **1.** 1) Шаярмыйча, җитди рәвештә, һич шаяртусыз. *Абзыйның соңгы соравы аны чынлап ук ачуландырды.* М.Әмир

2) *к.* **чыннан**. *Чынлап елагач, сукыр күздән дә яшь чыга.* Әйтем. *Чынлап уйласаң – үксез бала ич ул!* А. Гыйләҗев

**2.** *хәб. функ.* Раслауны белдерә: әйе, шулай, дөрес. *Чынлап, хәзер үк барабыз* // Сорауда шикләнүне белдерә. *[Таһирҗан:] Габдерахман ага, сез бездән көләсезме, әллә чынлапмы?* А.Гадел. *– Чынлапмы? – диде Мәннан, ышанмыйча.* Аманулла

◊ **Чынлап та** Әйтелә торган фикернең дөреслегенә басым ясау өчен кулланыла. **Чынлап торып** *к.* **чынлап**. *Талхәветдин инде хәзер, аяклары белән тыпырчынып, чынлап торып елый башлады.* А.Хәлим. *Чынлап торып көнләшә иде аның абыйсыннан Заир.* А.Нәҗми

**ЧЫНЛА́У** *ф. сөйл.* Берәр эшне дөрестән дә башкару, реаль эш үтәү. *Уйнаса – баласы җиңә, Чынласа – атасы җиңә.* Мәкаль. *Эчкече уйнар, аракы чынлар.* Мәкаль

**ЧЫНЛАШУ** *ф.* Җитдиләнү, җитдигә әйләнү; реаль төсмерләр алу; чынга ашу. *Яшьләр гөрләште Шатлык-моң белән! Көчләр чынлашты, Алга юл ачты, Курыкты төн, качты.* М.Җәлил

**ЧЫНЛЫК** *и.* 1) Реальлек; реаль тормыш. *Татар әдәбиятында да бу темага язылган әсәрләр булды, ләкин аларда, минемчә, чынлык җитми иде.* М.Хуҗин. *Төш – хыялланган чынлык үзе.* Р.Фәйзуллин

2) Чынбарлыкка туры килү; дөреслек, дөрес булу. *Чынлык булган җирдә ялган да бар.* Г.Морат. *Ярты-йорты дөреслек, шәләй-вәләй чынлык белән генә котылып булмаячагын да аңлады Хәлим.* Г.Гыйльманов

3) *сөйл. к.* **чынбарлык** (*1 мәгъ.*). *Җан өшеткеч куркыныч чынлык хатынны кинәт үзенә суыра башлады.* Г.Әдһәмова

4) Табигыйлык, ясалма булмау. *Сафлык, чынлык юкса күңелендә.* Р.Мостафин

**ЧЫНЛЫКЛЫ** *с. кит.* Ясалма булмаган, табигый; чын. *Соңгы сүзләрне әйткәндә, Михаилның тавышы бик чынлыклы һәм бераз каушанкырак чыга иде.* Ф.Әмирхан. *Хисләре аның чынлыклы һәм саф.* Мәдәни җомга

**ЧЫНЛЫКТА** *рәв.* Дөрестән дә, чынлап та. *Бу хәлләр барысы да чынлыкта булды*

**ЧЫННАН** *рәв.* **1.** *к.* **чынлап 1.** *Шуңа күрә мине бу мәсьәлә бик кызыксындыра: Москва округы запасныйларының барысы да чакырылганда, чыннан дамы миңа повестка булмады?..* М.Җәлил. *Чыннан ни әйтергә дә белмичә, теленә килгән бер сүзне тәкрарлады ---.* А.Хәлим. *Ул чыннан да ямьләнеп, күпереп, купшыланып киткән.* Ф.Яхин

**2.** *хәб. мәгъ. к.* **чынлап 2.** *Чыннан, мин алдамыйм*

◊ **Чыннан да** *к.* **чынлап та**

**ЧЫ́Н-ЧЫНЛАП** *рәв.* 1) Яхшылап, тиешенчә җитди төстә. *Чын-чынлап суытып та җибәрми, сүрән генә кояш чыгып ала да, кабат вак яңгыр белән алышына...* Л.Сабирова

2) Чын мәгънәсендә, бөтенләе белән, тулысынча. *Сезнең иншаны укыгач, ул Сөембикә ханбикә һәм аның манарасы белән дә, безнең татар халкы белән дә чын-чынлап кызыксынырлык булсын*! А.Әхмәтгалиева

**ЧЫ́Н-ЧЫННАН** *рәв. к.* **чынчынлап**. *Шәмси шушы барлы-юклы ике атна эчендә дә иптәшләрен чын-чыннан сагынуын хәзер бигрәк тә ачык сизде.* Г.Бәширов. *Чын-чыннан зыялы шәхесләр арасында да милли киеренкелек юк.* М.Юныс. *Мин бу сүзләргә чын-чыннан гаҗәпкә калам.* М.Вәлиев

**ЧЫНЫГУ** *ф.* 1) Бик югары температурада кыздырганнан соң, суынып, тагын да катырак, сыгылмалырак һәм ныгракка әйләнү (кайбер металлар һәм металл әйберләр турында). *[Кеше:] Без төзедек, кордык ут белән, ураклар да утта чыныкты.* К.Сибгатуллин

2) Төрле авыр климат шартларын кичереп, яшәүчәнлеген югалтмау, ныгу. *Ул инде чыныккан куак, суыкка да бирешерлек түгел.* Д.Аппакова

3) *күч.* Физик тәрбия белән нык, таза, авыруларга бирешмәүчән кешегә әйләнү. *[Айдар карт:] Отличниклар, сәяхәткә барыгыз, барыгыз. Юлыгызга ак җәймә. Тазарып, чынығып кайтыгыз.* Д.Аппакова

4) күч. Чыдамлыга, түземлегә әйләнү (аерым әгъзалар тур.). *Кара мыеклы, кысык күзле, битләре суыкка чыныккан кып-кызыл йөзле ямщик агайлар берсеннән-берсе хәйләкәр.* А.Хәсәнов

5) *күч.* Авыр шартларны кичерә алып, кыенлыкларга чыдарлык хәлгә килү. *Чыныкты яшь йөрәгем нык булып каты чуерташтан.* М.Җәлил. *Күп булса ун-унике көнгә сузылырга тиешле әлеге сәфәрдән Казанга Шәүкәт, сынаулар аша чыныккан үзенең сугышчан группасы белән, нәкъ ике атна тулган кичтә кайтып төште.* А.Хәсәнов

**Чыныга бару** Торган саен ныграк чыныгу. *Кулларым чыныга барды.* Н.Хәсәнов. *Үсә бардың һәм чыныга бардың.* Ф.Дәүләтгәрәева

**Чыныгып бару** *к.* **чыныга бару.** *Гомумән алганда, үсү һәм камилләшү юнәлешендә чыныгып бара торган әдәби телебезнең чарланасы, яхшыртыласы яклары юк түгел әле.* Ф.Хөсни

**Чыныгып бетү** Тәмам чыныгу. *Шуның өчен мәктәп тирәсенә яңгы мөгаллимнәр җыю түгел, искеләрне –*

*мәктәп исе белән чыныгып беткән мөгаллимнәрне тотып тору да фәүкыльгадә авырдыр.* Г.Исхакый. *Чыныгып бетмәгән гәүдәсенә көч кенә килмәсә ярар иде...* А.Әхмәтгалиева

**ЧЫНЫК** *с.* **1.** Чыныккан, чыныгу алган. *Янәсе, татар – чынык, Торабыз тыпырчынып.* Г.Морат

**2.** *и. мәгъ.* Чыныкканлык, ныклык. *Октябрьгә аны чынык җиткезде.* Г.Кутуй

**ЧЫНЫКТЫРУ** *ф. йөкл. юн. к.* **чыныгу**. 1) *Сандалга салып чүкеч белән чыныктырган ныклык белән яңгырыйлар бит.* А.Хәсәнов

2) Аерым культураларны, аларның орлыгын экстремаль шартларда тотып, төрле һава шартларына чыдам итеп әзерләү. *Әйтерсең табигать үсемлекләрнең тамырларына ут өрә, яктылык бөрки, аларны чыныктыра...* Ф.Садриев

3) Дөрес физик тәрбия бирү юлы белән физик яктан нык, чыдамлы кешегә әйләндерү. *Армия үз файдасын эшли: кешеләрне таныргa өйрәтә, физик чыныктыра, чын дуслар белән очраштыра.* Р.Рахман

4) Авырлыкларны җиңәргә, кичерергә өйрәтү, тәҗрибә бирү. *Бу һөнәр аларны чыныктыра, дөньяны таныргa өйрәтә, миһербанлы итә.* А.Хәсәнов

**Чыныктыра бару** Акрынлык белән, аз-азлап чыныктыру. *Бассейнда көн саен үткәргән күнекмәләр, урмандагы кросслар очучы организмын ныгыта, чыныктыра баралар.* Җ.Мостафин

**Чыныктыра башлау** Чыныктырырга тотыну. *Ул үзен салкынга, эссегә чыныктыра башлый.* Р.Батулла. *Аның бертуган абыйсын әти-әнисе бер айлык чагында ук шул рәвешле чыныктыра башлады.* Кызыл таң

**Чыныктыра килү** Күптәннән бирле чыныктыру. *Яшь каләм иясе үзен киләчәк өчен әнә шулай чыныктыра килгән.* Н.Гамбәр

**Чыныктыра тору** Берәр эш-хәлгә кадәр чыныктыру. *Сәбәпләрен алдан ук белеп торганда, бер-береңне югалтуның котылгысызлыгы хәвефкә әверелми, ә бары тик хисләрне чыныктыра тора.* К.Кәримов

**Чыныктыра төшү** Бераз чыныктыру; ныграк чыныктыру

**Чыныктырып алу** Бераз чыныктыру. *Яшь кадрларны авылларга җибәреп, сыйнфый көрәш шартларында чыныктырып алу турындагы фикер яңа булмаса да, бөтен кискенлеге белән ВКП(б)ның унбишенче съездында көн тәртибенә килеп басканын яхшы белә ул.* Ф.Сафин

**Чыныктырып бетерү** Тәмам, бик нык чыныктыру

**Чыныктырып җиткерү** Тиешенчә чыныктыру

**Чыныктырып кую** Алдан яки тиз арада чыныктыру

**Чыныктырып тору** Даими яки әледән-әле чыныктыру

**ЧЫНЫКТЫРУЧЫ** *и. махс.* Нинди дә булса металл эшләнмәне чыныктыру (*1 мәгъ.*) эше белән шөгыльләнүче эшче

**ЧЫҢ** *ият.* **1.** Кыңгырау, чаң һ.б.ш. металл әйберләргә сукканда, алар берберсенә бәрелгәндә чыккан тавышны белдерә

**2.** *и. мәгъ.* Металл әйберләр берберсенә бәрелгәндә барлыкка килгән тавыш. *Соңгысын суккач та, әле колак төбендә металл чыңы зеңләп торды, һәм инде тутыктан арынган бу нәзек чың дулкыннары, ике йөз яшьлек җиз сәгатьнең үзе кебек, саргылт төтен булып, талгын гына каядыр ерак-еракларга – үткән мизгелләргә, әллә соң киләчәккә табамы – сузылып, нечкәрә, җуела бара иде.* А.Тимергалин. *Сабакларының бер-беренә орынып чылтырашып куюы Сабантуй көннәрендәге кыңгыраулар чыңы булып ишетелә.* В.Нуруллин

**ЧЫҢГЫЛДАВЫК 1.** *с. диал.* Чыңгылдый торган; чыңлавык

**2.** *и. мәгъ.* Кечкенә кыңгырау, шөлдер. *Кич булганда, чыңгылдавыклар бәйләгән, шаңгырдавыклар таккан икешәр, өчәр атлы көймәләр, арбалар таралалар.* Шура́

**ЧЫҢГЫЛДА́У** *ф.* 1) Металл металлга бәрелгәндә һ.б.ш. очракларда үзенә бертөрле нечкә тавыш барлыкка китерү. *Хәтта чыңгылдап узган вагоннарга таба бер-ике адым хәрәкәт тә ясап карады.* Г.Кутуй. *Урамда чыр-чу, чыңгылдап, трамвайлар үтеп китә.* А.Гыйләҗев

2) *к.* **чыңлау** (2 мәгъ.)

**Чыңгылдап кую** Кинәт кенә чыңгылдау

**Чыңгылдап тору** Даими чыңгылдау; хәзерге вакытта чыңгылдау

**ЧЫҢГЫ́Л-ЧАҢГЫЛ** *ият. к.* **чыңгыл-чыңгыл**. *Ул, билендәге бомбаларын чыңгыл-чаңгыл китереп, бер рәвештәрәк йөри бирә.* М.Мансурова

**ЧЫҢГЫ́Л-ЧЫҢГЫЛ** *ият.* Металл металлга бәрелгәндә һ.б.ш. очракларда барлыкка килгән тавышны белдерә. *Фатыйма әби әлеге музыкаль сандыгын чыңгыл-чыңгыл итеп бикләде дә, ачкычын тәрәзә өстенә куеп, сәке түренә – Мәхмүтнең баш очына ук менеп утырды.* С.Шәкүров

**ЧЫҢГЫР** *ият.* Металлга металл бәрелгәндә барлыкка килгән, кечерәк кыңгырау чыгарган һ.б.ш. тавышны белдерә. *Чыңгыр гына чыңгыр дугалар, Китәләр дәмени кодалар.* Җыр

**ЧЫҢГЫРА́У** *ф.* 1) Металл металлга яки башка берәр нәрсә бәрелгәндә, чылбыр селкенгәндә һ.б.ш. очракларда үзенә бертөрле тавыш барлыкка килү. *Чыңгырады көмеш шпорым: – Лачыннарга тиң бул син, кашкам, Канатланып очыйк штабка! «Ашкын, ашкын, җирән аткаем!» – Дип озатып калды ак каен.* Ф.Кәрим. *Тагын буферлар чыңгырады.* М.Мәһдиев

2) Чыңлау, матур яңгырау

**ЧЫҢГЫРДАТУ** *ф. йөкл. юн. к.* **чыңгырдау**. *Арада иң яше дә, иң оста каз йолкучы да ул, иң матуры, иң чыңгырдатып көлүче дә ул.* Г.Бәширов

**ЧЫҢГЫРДА́У** *ф. сөйл. к.* **чыңгырау**. *Ул шалт-шолт винтовка агачына бәрә, затвор чыңгырдый.* М.Мәһдиев. *Ә көмеш кыңгырау тавышы бу вакытта һаман чыңгырдый, җаннарны айкап чыңгырдый иде.* Казан утлары

**ЧЫҢГЫ́Р-ЧЫҢГЫР** *ият. к.* **чыңгыл-чыңгыл**. *Кыймылдаган саен, аның күкрәгендәге орден-медальләр чыңгыр-чыңгыр килә иде.* М.Мәһдиев. *Әнисенең итәгенә тагылып эш хакы алышырга барган малай бинибая зур, авыр, чыңгыр-чыңгыр килеп ачыла торган тимер ишеккә шакката иде.* Д.Булатова

**ЧЫҢЛАВЫК** *с.* **1.** Чыңлап торган, яңгыравык. *Чыңлавык кыңгырау*

**2.** *и. мәгъ.* Кыңгырау. *Уң колагымда өзлексез чыңлавыклар чыңлыйлар.* Н.Исәнбәт. *Чылтыравык, чыңлавык. Синең көмеш тавышыңны Ун ел буе тыңладык.* В.Хәйруллина

**ЧЫҢЛА́У** *ф.* 1) Металл металлга бәрелгәндә һ.б.ш. очракларда үзенә бертөрле тавыш барлыкка китерү; металл тавышы чыгару. *Бер-бер артлы ике пуля ефрейторның каскасына тиеп чыңлады.* Г.Әпсәләмов

2) Кыңгырау яки юка металлдан эшләнгән эче куыш берәр әсбап, музыка коралы һ.б.ш. мелодик тавыш, чың барлыкка китерү. *Әлферитнең хыялларын челпәрәмә китереп, ишектә кыңгырау чыңлады.* А.Гыймадиев

3) Берәр прибор, җайланма мелодик сигнал бирү. *Телефон чыңлау*

4) Ягымлы тавыш чыгару, әһәңле, матур яңгырау

5) *күч.* Яңгыраган, ишетелгән кебек булу, күзаллану. *Синең белән бергә Көлгән төсле, Гармуның да ярсып чыңлады...* Л.Хәмидуллин

6) *күч.* Кагыйдә буларак, «колак», «чигә» сүзләреннән соң килеп, колакта, чигәдә берәр авыртулы тавыш тоюны белдерә. *Аның колакларында әле күптән түгел генә укылган хатның сүзләре чыңлады.* Г.Әпсәләмов

**Чыңлап алу** Кыска гына вакыт чыңлау. *Сандугач тавышлы телефон чыңлап алды.* А.Вергазов. *Күңелләрдә бер кыл чыңлап ала.* Г.Гыйльманов

**Чыңлап китү** Кинәт кенә чыңлау. *Шул сүзне ул тавышын зурайтыбрак әйттеме --- шул җөмләләр чыңлап китте.* Г.Исхакый

**Чыңлап кую** Бер тапкыр, кинәт кенә чыңлау. *Бүлмә эчендә тоныкһәм ятим булып кыңгырау чыңлап куйды.* А.Вергазов. *Елга аръягында кыңгыраулар чыңлап куйды.* А.Хәлим

**Чыңлап тору** Даими чыңлау; хәзерге вакытта чыңлау. *Тәрәзә пыялалары берөзлексез чыңлап тора.* Г.Әпсәләмов. *Кичләрен рестораннарда оркестр чыңлап тора.* А.Гыйләҗев

**ЧЫҢЛЫ** *с. сөйл.* Чыңлый торган, чыңлау авазлары чыгара торган. *Печән чабам киерелеп, Уйный кулда чыңлы чалгы.* И.Әширов

**ЧЫ́Ң-ЧЫҢ** *иярт.* Металл металлга, пыяла пыялага кат-кат бәрелгәндә һ.б.ш. очракларда барлыкка килгән яңгыравык тавышны белдерә. *[Разия:] Туйда, дугада, чуар сөлгеләр арасында чың-чың итсен иде алар!* А.Гыйләҗев. *Чың-чың итә, җил тузгыта Җиз кыңгырау моңнарын.* А.Хәсәнов

**ЧЫП-** *кис.* [ч] авазына башлана торган кайбер сыйфатларның артыклык дәрәҗәсен ясау кисәкчәсе. *Алтын капка каршындагы кырда, боздан ясап, чып-чын кирмән-кала торгызырга*! В.Имамов. *Хәлил үзе чып-чын ирләр эшен башкара югыйсә.* Ф.Мөслимова

**ЧЫПТА** *и. фар.* **1.** Мунчала, салам, нечкә чыбык һ.б.ш.дан сугылган тупас тукыма. *Аннан калган җиргә элек камыш чыпта, аның өстенә кара тузган киез түшәделәр.* Г.Ибраһимов. *Сабирҗан мәзин ярлы йортларга яңадан чыпта сугарга мунчала өләшә башлады.* М.Галәү

**2.** *с. мәгъ.* Шундый тукымадан ясалган, шуннан тегелгән. *Буяулы ишкәктән чыпта җилкән артык.* Әйтем. *Идәндә, аяк астында юкә төргәге, үрелгән чыпта тасмалар аунап ята.* Н.Фәттах

**ЧЫПТАЛЫ с.** Чыпта белән тышланган (арты биек тирән чана яки арба тур.). *Ул арада арты чыпталы чанага аллы-артлы җигелгән ике ат болар янына йортның аргы ягыннан чаптырып килеп тә туктады...* Г. Ибраһимов. *Агай кызны җәлт кенә күтәреп чыпталы арбага утыртты, аркасыннан сыйпап сөйде.* Х.Ибраһим

**ЧЫПТАЧЫ** *и.* Чыпта сугучы оста. *Чыптачы, гөрселдәп, җиргә килеп төште...* М.Галәү. *Бер көнне чыптачы Хөсәен абзый Габдулланы, арбасына салып, Казанга – бер танышына алып китә.* Туган як

**ЧЫПЧЫК** *и. зоол.* Чыпчыккошлар семьялыгыннан көрән-соры төстәге кечкенә кош. *Агач ботакларында, койма өсләрендә, начар хатыннар шикелле, ярты гомерен үзара әрепләшеп, ызгышып уздыручы чыпчык халкы чыркылдый.* Г.Бәширов. *Бер көтү чыпчык, сарытүш, карабүрек, соры песнәкләр шуннан җим чүпләп кинәнәләр.* А.Хәсәнов

◊ **Чыпчык борыны чаклы (хәтле)** Бик аз; бөтенләй юк. *Заполярьеның җәе чыпчык борыны хәтле генә.* Г.Әпсәләмов. *Ә эше чыпчык борыны чаклы гына.* Ш.Галиев. **Чыпчык җиле** Көчсез, әкрен җил турында. *Үзәннәрдә искән чыпчык җиле түгел инде ул – тауда сызгырган бөркет җиле, егетләр җиле!* А.Гыйләҗев. **Чыпчык тезеннән** 1) Бик сай (елга, күл тур.). *Инеш дигәч тә, кай җирләрдә ул чыпчык тезеннән генә.* А.Хәсәнов. *Бергәләп каз көткән инеш буйлары да үзгәрде: суы чыпчык тезеннән генә калды.* А.Әхмәтгалиева; 2) Бик аз, бик кечкенә. *Тик ни файда, көчең филдәй булып, Эшең булса чыпчык тезеннән.* М.Җәлил. **Чыпчык чүпләп бетермәс** Бик күп. *Ул чын-чынлап хуҗа, аның вазифаларын чыпчык чүпләп бетермәс: иртән иң беренче уянып, дөньяга тавыш бирә.* Н.Гыйматдинова

**ЧЫПЧЫ́К АЯГЫ** *и. диал. к.* **каз үләне**

**ЧЫПЧЫКБАШ** *и. кимс.* Аңгыра, тинтәк. *Сездиләргә, сезгә: «Чыпчыкбаш», – диләр.* Г.Тукай

**ЧЫПЧЫ́К БОРЧАГЫ** *и. бот.* Кузгалакчалар семьялыгыннан үләнчел үсемлек

**ЧЫПЧЫ́К ҖИЛЕМЕ** *и. бот.* Канәферсыманнар семьялыгыннан куе кызыл чәчәкле, болында үсә торган үләнчел үсемлек

**ЧЫПЧЫКЙӨРӘК** *и.* Куркак кеше. *[Сафа:] Чыпчыкйөрәк булма.* И.Катиев

**ЧЫПЧЫ́К КУЗГАЛАГЫ** *и. бот.* Кузгалакның бер төре, төче кузгалак; *русчасы:* **щавелёк**

**ЧЫПЧЫК КҮЗЕ** *и. диал. к.* **күгәрчен күзе**

**ЧЫПЫЛДАТУ** *ф. сөйл. к.* **чапылдату**. *Үзе, уйга калып, ана сөте кипмәгән иреннәрен чыпылдата.* Я.Шәфыйков. *Вәлкәй, берзаман, авызларын чыпылдата-чыпылдата, Шәмсияне үзенә яшь хатынлыкка димли башлады, өрмәгән җиргә дә утыртмаска вәгъдәләр яудыра, балда-майда гына йөздерермен, дип ант эчә иде.* Ф.Сафин

**ЧЫПЫЛДА́У** *ф. сөйл. к.* **чапылдау**. *Аяк астында су чыпылдый, түбәдән тамчылар тама, таш баскычлар тайгак, менә-менә таеп, мәтәлеп китәрсең кебек.* М.Хәбибуллин

**ЧЫПЫР** *кис. диал.* Чат, гел, бөтенләй. *Карлы-бозлы яңгыр ява, аяк асты чыпыр су, акыллы кешеләр өйдә генә утыра торган ямьсез вакыт.* Т.Әйди

**ЧЫПЫРДА́У** *ф. сөйл. к.* **чупырдау**. *Бер якта яңа сугылган паласның керен чыгаралар, келәм чистарталар, икенчесендә балалар чыпырдый.* Т.Әйди. *Кайчаннан бирле суда чыпырдый бу. Чәй суынып бетте.* Р.Мулланурова

**ЧЫПЫР-ЧЫПЫР** *иярт. к.* **чупыр-чупыр**. *Менә самавырдан чыпыр-чыпыр килеп су акты.* Н.Дәүли. *Ат юлдагы күлләвекләрне чыпыр-чыпыр китереп юырта.* М.Әмирханов

**ЧЫР** I *и.* Ит, итле аш яки ит пешергәндә шулпа өстенә чыккан май; өре. *Майлы иттән чыр күп чыга.* Мәкаль

**ЧЫР** II *и. иск.* Матурлык, нәфислек. *Көндез күзе ачылмаган егет чыр күрмәс.* Мәкаль

**ЧЫР** III *иярт. к.* **чер**. *Кинәт чыр иткән авазлар купты, һәм кешеләр, рәшәткә тимерләре арасыннан эчкә кергән нәни кызны күреп, телсез калдылар.* М.Хуҗин

**ЧЫРА** *и.* 1) Ут кабызып җибәрү, элек өй эчен яктырту өчен, киптерелгән агач пүләненнән җепселләре буйлап бик юка итеп телеп алынган кисәк, бик юка агач телеме. *Газинур, менә шул бүреләрдән саклану чарасы итеп, букчасында өч ел рәттән бер бәйләм коры чыра йөртте.* А.Хәсәнов. *Кабызган чыра бик тиз*

*сүнеп бетә, аннары, Сәүбәнгә эчкәрәк керүнең кирәге дә юк иде.* Г.Гыйльманов

2) Гомумән юка кыска агач телеме, таяк кисәге

◊ **Чырага калу** Бик ныкябыгу. *Толымбикә коры чырага калган иде, йөз-бите уңган киндер төсендә.* М.Әмирханов

**ЧЫРАГ** *и. фар.* 1) *иск. к.* **чыра**. *Муса әмирнең баш очында ике чыраг тоныккына яктылык сирпеп янып тора.* Р.Батулла // Гомумән, яктылык чыганагы. *Кыз – башка йортның чырагы.* Әйтем

2) Гыйлем, мәгърифәт һ.б.ш. чыганагы; шуларның символы. *Журналның кәгазе – сезнең өчен көзге, Алдыгызда яктыртылган чыраг ул.* Г.Тукай

3) *күч.* Үрнәк алырлык зат, маяк, идеал

4) *күч.* Өмет һ.б.ш. чыганагы, рухи таяныч. *Атам үлде – аркам сынды, анам үлде – чырагым сүнде.* Әйтем. *Кала бер юл: татарларның Мәккәсе, күңеленең тирән бер почмагында яшерен генә пыскыган чыраг булган Казанга сәфәр кылу.* К.Тинчурин // Сөйгән, якын кешегә эшдәшү һәм аны атау сүзе

**ЧЫРАГАЧ** *и.* Чыра телеп алу өчен киптерелгән утын агачы, утын пүләне, чыралык. *Имән агач – каты агач, Каен агач – чырагач.* Г.Гомәр. *Әнисе бердәнбер улының кайнар мичтәге чырагач кебек күзгә күренеп көйрәвен бик тиз күрде.* М.Хәсәнов

**ЧЫРАЙ** *и. монг.* Кешедәге эчке хәлнең чагылышы буларак йөз, төс, бит; кешедәге физик яки рухи хәлнең йөздә, төс-биттә чагылышы. *Ләкин Асылов без белгәннәрне бик азсынып, сытык чырай белән баш чайкап утырды.* А.Гыйләҗев. *Рәдифнең әнисе Мәсрүрә апа безне якты чырай, ачык йөз белән каршылады.* В.Нуруллин

◊ **Чырае качкан** Кинәт курку, авырту һ.б.ш. хәлләрдән бик нык агарынган, үзенең табигый төсен югалткан. **Чырае киткән** *к.* **чырае качкан**. **Чырае көл кебек** *к.* **чырае качкан**. *Башы ак белән бәйләнгән иде аның, кояш яхшы ук кыздыруга карамастан, чырае көл кебек, йөзендә әз генә дә кан әсәре сизелми.* Г.Гобәй. **Чыраена чыгу** Рухи яки физик халәте йөзендә чагылу. *Шулай да Фатихның чыраена чыккан мәнсезлеккә үзенең ризасызлыгын белгертми кала алмады.* Ф.Яруллин. *Хәсибә апаның куркуы чыраена чыккан иде.* З.Кадыйрова. **Чырай сыту** Канәгатьсезлек, ризасызлык белдереп, йөзнең табигый кыяфәтен үзгәртү. *Фатыйманың чырай сытуы әлеге кешене гарьләндерде.* Г.Минский. *Ул, җәрәхәтенә тоз сипкәндәге кебек, чыраен сытты, күңелсезләнде.* А.Әхмәт

**ЧЫРАЙСЫ́З** *с.* 1) Йөзе табигый төсен югалткан. *Төссез, чырайсыз Мәрхәмбикәне күреп, Хәмит шүрли калды.* М.Хәсәнов

2) Йөзе башка кешеләрнекеннән төссезрәк, ямьсез; чырсыз. *Күземне ачып карасам, кырган сакаллы, сары мыеклы, үлгән сарык күзле, чырайсыз бер сыщик күзене акайтып тора.* Г.Исхакый

**ЧЫРАЙСЫ́З ЯБАЛАК** *и. зоол.* Ябалакчалар семьялыгыннан төнлә ауга чыга торган көрән төстәге ерткыч кош; *русчасы:* **сыч**. *Чырайсыз ябалакны урман да куган, авыл да куган.* Әйтем. *Уртача зурлыктагы һәм вак ябалаклар – колаклы ябалак, сазлык ябалагы, соры ябалак һәм бигрәк тә кечкенә чырайсыз ябалак авыл хуҗалыгына шактый файда китерәләр.* Биология

**ЧЫРАК** *и. диал. к.* **чыраг**. *Караңгы төн исә – як чыраклар.* Дәрдемәнд

**ЧЫРАКЧЫ** *и. иск.* Төнлә көймәдә басып торып, чыра (ут) яктысына аулап, салдау белән чәнчеп балык тотучы. *Чыракчыны чуртан күрмәс.* Әйтем

**ЧЫРАЛАНУ** *ф.* Яргаланып чырага әйләнү, чыралар барлыкка китереп телгәләнү. *Абзарның юан имән өрлеге чыраланып, урталай өзелгән.* Казан утлары

**ЧЫРАЛЫ** *с.* Чыралар кулланылган, чыралар куелган. *Чыралы умарта – корт балны умартаның стенасына җыймасын өчен, рамлы умартага кадәрге, аның югары өлешенә чыралар урнаштырылган багана умарта*

**ЧЫРАЛЫК** *с.* **1.** Чыра өчен яраклы булган, чыра өчен билгеләнгән. *Патый пычак, чыралык агач һәм чыраларны кочагына җыеп мичкә ташлады, куллларын корсагы турысына кушырып, күлмәгенең бала итәге астына яшерде ---.* М.Галәү

**2.** *и. мәгъ.* Чыра өчен билгеләнгән утын, чыра өчен яраклы ярка. *[Шәмгун:] Утын урлап йөримме? Чыралык өчен киптерергә алып кайтканымны күргәннәрдер.* Т.Гыйззәт. *Көндез чыра яндырып эзләсәң дә, чыралык та юк.* Ш.Галиев

**ЧЫРК** *иярт.* Берәр агач яки агачтан эшләнгән әйбер сынганда, берәр авыр нәрсә җиргә төшеп ватылганда яки аны берәр нәрсәгә китереп бәргәндә һ.б.ш. очракларда барлыкка килгән тавышны белдерә. *Биш кадаклы салмак гер, чырк итеп, ялтыр түбәгә кунып алды.* М.Галәү. *Караңгы булса да, үз күзем белән күрдем: кирпеч чырк итеп урталай ярылды.* Д.Гыйсметдин

**ЧЫ́Р КИЛҮ** *ф. к.* **чыр-чу килү**. *Апаларын да кочып, аларның чыр килүләренә дә карамастан, борын очларыннан гына пәп итеп чыкты.* А.Хәсәнов

**ЧЫРКЫЛДАТУ** *ф. сөйл.* 1) *йөкл. юн. к.* **чыркылдау**. *Тилгәннәр дә тавык чебешләрен, каз бәпкәләрен чыркылдатып алып китәләр бит...* А.Хәлим

2) Каты итеп, кинәт егу, җиргә китереп салу, бәрү. *[Нәсимә:] Тәти абый, җаным, шул Әзмәвер пәрине, сыны катырлык итеп, бер чыркылдатсаң, ә?* И.Гази

**Чыркылдата башлау** Чыркылдатырга тотыну

**Чыркылдатып йөрү** Билгеле вакыт дәвамында чыркылдату. *Егет чак бит, кызларны кочаклаган булып чыркылдатып йөрү – үзе кызык.* И.Юзеев

**Чыркылдатып тору** Гел, даими чыркылдату; хәзерге вакытта чыркылдату

**ЧЫРКЫЛДА́У** *ф.* 1) Үзенә бертөрле тавыш белән кычкыру, сайрау, чырык-чырык килү (кайбер кошлар тур.)

2) *сөйл.* Бик югары яки яңгыравыклы тавыш белән сөйләү, көлү, кычкыру; чырылдау. *Ишек ачылды, эчтән көлгән, чыркылдаган тавышлар килде.* А.Гыйләҗев. *Кызлар, колакларын томалап, чыркылдап, читкә сибелделәр.* А.Әхмәтгалиева

**Чыркылдап алу** Бераз чыркылдау. *Кызлар, бер-берсенә борылгалап, чыркылдап алдылар, егетләр җанланып көлеп җибәрде ---.* Г.Бәширов

**Чыркылдап тору** Даими, гел чыркылдау; хәзерге вакытта чыркылдау. *Чыркылдап торган балаларга, яшьләргә карыйм.* Ш.Галиев

**Чыркылдый башлау** Чыркылдарга тотыну. *«Чыпчык» тагын да күңеллерәк чыркылдый башлады.* Н.Гыйматдинова

**ЧЫРКЫЛДАШУ** *ф. урт. юн. к.* **чыркылдау.** *Балчык өеменнән селәүчән бүлешә алмыйча, тагын да чыпчыклар чыркылдашты.* А.Хәлим. *Мин исемнәрен белми торган бик күп кошлар чыркылдаштылар.* А.Гыйләҗев

**ЧЫРКЫЛДЫК** *с. сөйл.* **1**. 1) Чырык-чырык сайрый, шундый тавышлар чыгара торган. *Менә без – унбер кыз һәм, чыркылдык чәүкәләр арасында калган бердәнбер карга сыман, мин – барыбыз беравыздан уенның такмагын көйләргә тотындык.* Г.Бәширов

2) Югары яки яңгыравыклы тавыш белән сөйләшә, көлә торган. *Күл өстенә аның чыркылдык тавышы таралды.* Н.Гыйматдинова

**2.** *и. мәгъ. кимс.* Югары яңгыравык тавыш белән сөйләүче кеше. *Аннан мин, чыркылдык булсам да, тегендәмонда йөрмәдем бит, Рәфикъ, өйдә генә чыркылдап ятадыр ием.* Р.Юныс

**ЧЫРКЫ́Н-ЧЫРКЫН КИЛҮ** *ф. диал.* Уйнау-көлү, шаяру (хатын-кыз һәм бала-чага тур.)

**ЧЫРЛА́У** *ф.* 1) Кайбер кошларның сайравы һәм аерым бөҗәкләрнең тавыш чыгаруы. *Туксансыз тургай чырламас.* Әйтем. *Арыш арасында чикерткәләр колак яргыч итеп чырлый.* Р.Батулла

2) *к.* **чылтырау.** *Елга әнә чырлап ага.* Ә.Сәгыйди

**Чырлый башлау** Чырларга тотыну

**Чырлап тору** Даими чырлау; хәзерге вакытта чырлау

**ЧЫРЛЫ** I *с.* Чыры (I) булган, өреле. *Чырлы аш*

**ЧЫРЛЫ** II *с. диал.* Матур, чибәр. *Сүләшәм-сүләшәм, йомгакның очына чыга барам: шыл Майтап атлы чырлы толга минем фронтовик дусның күзе төшеп тора, имеш.* Ф.Хөсни

**ЧЫРМАШУ** *ф. диал.* Чорналу; сабаклары бер-берсенә керешеп үсү. *Тырыш тырмашыр, колмак чырмашыр.* Әйтем

**ЧЫРПАЛУ** *ф. диал.* Чатнау, ватылу, тетелү. *Таулар ярылып, ташлар чырпала.* М.Җәлил

**ЧЫРСЫЗ** I *с.* Чыры (I) булмаган, өресез. *Чырсыз шулпа*

**ЧЫРСЫЗ** II *с. диал.* **1.** Ямьсез, шыксыз, чибәр булмаган. *Кабат һушыма килгәндә, янымда чырсыз ат (ул агачка бәйләнгән иде) һәм Гөлчәчәк басып торалар иде.* З.Хөснияр

**2.** *и. мәгъ.* Ямьсез, шыксыз кеше. *[Зәмзәмбану:] Әй чырсыз, чырсыз, харап иткәнсең бит.* Т.Гыйззәт

**ЧЫРТ** *иярт.* Агач сынганда, теш арасыннан төкергәндә һ.б.ш. вакытта барлыкка килгән кыска өзек тавышны белдерә. *Өстәл өстендәге калын пыяла чырт итеп урталай сынды.* Р.Батулла

**ЧЫРТАН** *и. диал. к.* **сарут**. *Ике чыртан яктырды, Идегәйне йөгентеп Арасыннан үткәрде.* Дастан

**ЧЫРТЛА́У** *ф.* Коры шытырдау, чатнау кебек кыска тавышлар барлыкка китерү; чырт-чырт итү. *Җәй буе кибеп, тимәс борын чыртлап сынып торган каен ботакларыннан корылган куыш соңгы мәртәбә авыр итеп сулыш алды да әлеге ачыргалану авазы өстенә җимерелеп төште.* Г.Гыйльманов. *Керде, чыкты хуҗабикә, савыт-саба шалтыратты, мичкә якты, чыртлап, утын янганы ишетелде.* К.Кара

**Чыртлый башлау** Чыртларга тотыну

**Чыртлап тору** Даими чыртлау; хәзерге вакытта чыртлау

**ЧЫ́РТ-ЧЫРТ** *иярт.* Чыбык, кипкән үлән сабаклары сынгалаганда һ.б.ш. вакытларда барлыкка килгән өзек-өзек тавышларны белдерә. *Әнә ул, чырт-чырт китереп, өстендәге ефәк күлмәген салып атты, чаршау өстендә очлы башлы ике нәни алма уйнаклады.* В.Имамов

**ЧЫ́РТ-ЧЫРТ ИТҮ** *ф.* Чырт-чырт кебегрәк тавыш чыгару. *Хәкимҗан абзыйның чырае яктырып китте, ул ике куллап чутка ябышты һәм, чырт-чырт итеп, төймәләрне авыштырды.* А.Гыйләҗев. *Шулчак якында гына, чыртчырт итеп, коры куак чыбыклары сынган тавыш ишетелде.* А.Хәсәнов

**ЧЫР-ЧУ** *и.* 1) Югары тавыш белән көлешү, сөйләшү, кычкырышу тавышлары. *Кинәт якында гына исерек җыр ишетелде, аннары чыр-чу купты, һәм, бөтен су өсләрен яңгыратып, кемдер ачы тавыш белән кычкыра башлады ---.* Г.Әпсәләмов. *Урамда чыр-чу, чыңгылдап, трамвайлар үтеп китә.* А.Гыйләҗев

2) Кайбер кошларның чыркылдашу тавышы. *Әллә инде безнең якларга да Иләшүте чыпчык карагы – Чыр-чу сирәк хәзер...* Г.Морат

**ЧЫР-ЧУ́ КИЛҮ** *ф.* 1) Югары яңгыравыклы тавыш белән сөйләшү, кычкыру. *Бераздан болар, чыр-чу килеп, ике егетне өстерәп тә кертте.* В.Имамов. *Бигрәк тә яшь кыз-хатыннар чыр-чу килделәр, шатлыклары эчләренә сыймады.* З.Кадыйрова

2) Кошлар чырылдау, чыркылдашу. *Рушания да аның янына скамейкага килеп утырды, ул да чыр-чу килгән тургайларга карады.* З.Кадыйрова

**ЧЫ́Р-ЧЫР** *иярт.* 1) Кайбер кошлар чыркылдаган, кычкырган тавышны белдерә. *Ишетәсеңме, болары ничек итеп чыр-чыр килеп җылыйлар?!* А.Гыйләҗев

2) Җанлы-җансыз нәрсәләр чыгарган коры сызгыручан тавышны белдерә. *Атлаган саен чыр-чыр итеп таяклары «сыкравыннан» һәм чаңгылары чыжылдавыннан башка дөньяда һичнинди тавыш та юк иде.* В.Нуруллин

3) Ачы яки югары нечкә тавыш белән сөйләшү, кычкырышу тавышларын белдерә. Ул *арада эчке бүлмәдән чыр-чыр иткән бер яшь хатын тавышы килде.* Г.Ибраһимов. *Чиртмәс борын чыр-чыр киләсең, нәрсә, син ир түгелме әллә?* Г.Гыйльманов

**ЧЫРШАЮ** *ф. диал.* Бөрешү, җыерчыклану. *Чыршайган битле карт*

**ЧЫРШЫ** *и.* **1.** Наратчалар семьялыгыннан конуссыман ябалдашлы мәңге яшел ылыслы агач. *Тау битенә нарат, чыршы агачлары үскән.* Г.Әпсәләмов. *Ябалдаш чыршы астында утыра.* В.Нуруллин

**2.** *с. мәгъ.* Шул агачтан ясалган, төзелгән. *Чыршы бүрәнәдән салынган йорт*

**ЧЫРШЫ́ БӘЙРӘМЕ** *и.* Яңа ел алдыннан бизәлгән чыршы тирәсендә җыр, бию һәм төрле уеннар белән үткәрелә торган балалар бәйрәме. *Яңа елның чыршы бәйрәмнәрен уйнап-көлеп үткәрдек.* Г.Мөхәммәтшин

**ЧЫРШЫ́ ГӨМБӘСЕ** *и. бот. к.* **җирән гөмбә**

**ЧЫРШЫЛЫК** *и.* Чыршы үсә торган урман, чыршы урманы; чыршы утыртылган урын. *Кеше үтә алмаслык куе чыршылык башланды.* Г.Әпсәләмов. *Түбәнрәк төшсәң – чыршылык.* М.Мәһдиев

**ЧЫРШЫН** *и.* Бал кортлары кәрәз күзәнәкләренә тутыра һәм ашамлык итеп куллана торган чәчәк серкәсе, чәчәк тузаны; бал корты икмәге. *Шул арада ул Нурисламның кайбер сорауларына кыскача гына булса да җавап бирергә ашыкты: – Беренчедән, – диде ул, – мин әче балга, башкалардан аермалы буларак, чүпрә салмыйм. Аның урынына балның ипиен, ягъни дә чыршын салам.* Г.Галиева. *Кортка фәкать бал белән чыршын, ягъни бал икмәге, перга кирәк.* Б.Камалов

**ЧЫРШЫ́ ҮЛӘНЕ** *и. бот. к.* **нарат-баш**; *русчасы:* **хвощ**

**ЧЫРЫЙ** *иярт. к.* **чер**. *Мөдәррис исемле малайның чырый итеп кычкыруына борылып карадык.* Казан утлары

**ЧЫРЫЙЛА́У** *ф.* Ачы нечкә тавыш белән кычкыру. *Җиңги: – Самат абый, нишлисең? Җибәр, әтү разбуй салам! – дип, чырыйлап кычкырып куйды.* В.Нуруллин. *Хатынның чырыйлап кычкыруын ирнең карлыккан тавышы күмде.* А.Әхмәтгалиева

**ЧЫРЫК** *иярт. к.* **чырк**. *Шулай диде дә кинәт башын сәкегә чырык итеп бәреп ауды.* М. Мәһдиев

**ЧЫРЫ́К-ЧЫРЫК** *иярт.* 1) Кошларның сайравын яки чыркылдаган тавышларын белдерә

2) Артык кычкырмыйча, тыйнак кына, җиңелчә көлүне белдерә. *Гөлзада исә туктаусыз чытлыкланды, аны төрлечә шаяртты, үртәде, чеметте, муенына көнбагыш, борчак, чуерташ салды, пычрак булса – сазга этеп кертте, кыш көне кар белән коендырды, үзе чырык-чырык көлде дә көлде.* Ф.Садриев. *Кызчык, аларның кулына асылынып, чырык-чырык көлде...* Г.Әдһәмова

**ЧЫРЫЛДАВЫКЛЫ** *с.* Чырылдый торган, ачы нечкә (тавыш тур.). *Дивардагы иске сәгать, Камәретдиннең тавышына охшаган чырылдавыклы тавыш белән, тугызны суга башл[ый].* К.Тинчурин

**ЧЫРЫЛДАТУ** *ф.* 1) *йокл. юн. к.* **чырылдау**. *Марат, сеңлесенең бу сүзләренә түзә алмыйча, Рәмзияне куып китә һәм, бер эләктерсә, нык кына чырылдата.* Ф.Яруллин

2) *сөйл.* Сызгырту. *Ул әле шап иттереп учын учка сугып ала, әле чырылдатып сызгырып җибәрә, әле чүгеп куя.* М.Галәү

**ЧЫРЫЛДА́У** *ф.* 1) Кайбер кошлар, бөҗәкләр нечкә тавыш белән кычкыру. *Кипкән печән исенә алма исе килеп кушыла да баш әйләнеп китә, ә җылы кичтә бакча тутырып чикерткәләр чырылдый.* М.Мәһдиев. *Өстә генә тургайлар чырылдый...* А.Гыйләҗев. *Озын колгадагы ояда сыерчык балалары, көнләп-сәгатьләп, күзгә күренеп үсәләр, чырылдый-чырылдый очарга талпыналар.* Н.Каштанов

2) Ачы нечкә тавыш белән кычкыру. *Бала-чага елаша, хатын-кыз чырылдый.* А.Гыйләҗев

3) Металл детальләр, ышкылып, кискен тавыш барлыкка китерү. *Шул мәлне кинәт телефон чырылдый башлады.* С.Зыялы

**ЧЫТ** *и. иск.* Ситсы, бизәкле ситсы; миткаль

**ЧЫТАЮ** *ф.* 1) *диал.* Үпкәләп, ризасызлык белдереп чырай сыту, турсаю. Аның йөзе чытайды

2) Чымырдау, шундый тойгы сизү. *Минем әле йокым туеп җитмәгән, күзләрем ачыта, чирәмнең салкын чыгында аякларым чытая.* Г.Бәширов

**Чытаеп китү** Кинәттән чытаю

**Чытаеп кую** *Кинәт, кисәк кенә чытаю. Әмма Таһир бераз чытаеп куйды әле ---.* А. Хәсәнов. *Хатын кинәт чытаеп калтыранып куйды.* Д.Вәлиев

**ЧЫТЛАНУ** *ф. диал. к.* **чытлыклану**. *Ялгыз алма багларында сандугачлар, Чытланышып, назланышып, сызланышып, Ниндидер дәртле аһәң моңлап алды.* Ш.Монасыйпов. *Нинди шук вә хуш аһәңле Шигырь әйтүләр вә сүзләре, Чайкалып, чытланып Йөргән чакта Ритмик адымнар.* Б.Урманче

**ЧЫТЛЫК** I *с.* 1) Үз-үзен тотуы, кыланышы белән ирләргә охшарга тырыша торган (малайлар тур.). *Тиктормас, чытлык малайлар, йөз мәртәбә кисәтәсең – юк, онытылалар да немец снайперына азык булалар.* Х.Камалов. *Чытлык үсмерне укучылар ярата, укытучылар сөйми.* Р.Батулла

2) Кыланучан, сырланучан, кыланчык (кызлар тур.) *Сүгенә белмә, тәмәке тартма, тавышың – чытлык кызларныкы...* М.Мәһдиев. *Ул чытлык кызлар һәрвакыт аңа үзләре ятьмә коралар, очраклы, көтелмәгән әллә нинди очрашулар оештыралар.* З.Хөснияр

**ЧЫТЛЫК** II *и. диал.* Ешлык, чытырманлык

**ЧЫТЛЫКЛАНУ** *ф.* 1) Кылану, сырлану; үз-үзен тотуда табигыйлык булмау. *Гөлзада исә туктаусыз чытлыкланды, аны төрлечә шаяртты, үртәде, чеметте, муенына көнбагыш, борчак, чуерташ салды, пычрак булса – сазга этеп кертте, кыш көне кар белән коендырды, үзе чырык-чырык көлде дә көлде.* Ф.Садриев

2) Әтәчләнү, батыраю, әрсезләнү. *– Черкидәме? – ди малайларның берсе, чытлыкланып.* М.Галиев

**Чытлыклана башлау** Чытлыкланырга тотыну. *Рухия, Равил күреп торган чакларда, бүтән малайлар янында юри чытлыклана башлады.* В.Нуруллин

**Чытлыкланып алу** Аз гына чытлыклану

**ЧЫТЛЫКЛЫК** *и.* Характердагы чытлык булу сыйфаты, кыланчыклык. *– Ә ул мине үзе чакырды, – диде кыз, һәм аның тавышында ниндидер бер чытлыклык, кыланчыклык бар кебек иде.* Н.Акмал

**ЧЫТУ** *ф. диал.* к. **сыту**. *Ялганлыйсың, йөзеңне дә чытмыйсың, шушы кадәр бөҗәкләр алдында берәүгә дә зарар китермибез.* А.Алиш. *– Ә минем рюкзак авыр булыр, һай авы-ы-р... – диде ул, йөзен чыткан булып.* А.Гыймадиев

**ЧЫ́Т-ЧЫТ** *иярт. к.* **чет-чет**. *Айбулатның йомшак мөгамәләсе әлегә аның күз яшьләрен тыеп торса да, күңеле мөлдерәмә тулган иде, ахры, авырайган, дымланган күз-керфекләрен чыт-чыт йомгалый башлады.* Т.Әйди

**ЧЫ́Т-ЧЫТ ИТҮ** *ф.* Чыт-чыт кебек тавыш чыгару. *Шушы эш, чыт-чыт итеп, төймә белән йөзәр, меңәр тәсбих санауга күрә дә, ихтимал, саваплы бер гамәл булыр.* Р.Фәхретдин

**ЧЫТЫЙ** *с. диал.* Чытлык, кыланчык. *Фәридә алар арасыннан кемнән дә булса оялган чытый кыз шикелле елмаеп карый торган җәннәт кояшын күрә.* С.Җәлал

**ЧЫТЫ́ЙН-ЧОТЫЙН** *рәв. сөйл.* Алпан-тилпән. *Нәрсә син, исерек аю шикелле, чытыйн-чотыйн атлыйсың?* Г.Бәширов

**ЧЫТЫК** *с.* 1) *сөйл.* Табигый булмаган төс-кыяфәт чыккан, бозылган (йөз тур.). *Әсирләрнең сакал-мыек баскан ябык йөзләре чытык, күз карашлары сүнгән, рухлары төшкән.* Г.Әпсәләмов. *Атасы кебек үк чытык йөзле Котан ярга сикерде.* Н.Фәттах

2) *күч.* Явым-төшемле, сүрән, бозык (һава тур.). *Язгы гөлләр белән Мин дә туңам. Чытык көн шикелле Күңлем тула.* Г.Морат. *Үзем күреп тордым: сүрән, чытык көннәрдән соң юкә яфраклары, каен ботаклары, өянкеләр, көчле имәннәр, бугазларын киереп, йотыга-йотыга эчтеләр кояшның кайнар нурларын.* Р.Харис

◊ **Чытык йөзле** Болытлы, явым-төшемле. *Күк ачулы. Чытык йөзле.* Г.Ибраһимов. *Тик менә кар катыш яңгыр явып торган чытык йөзле көзге көннәрнең берсендә үзен судка чакырып кәгазь килгәч кенә, Гәрәевнең кәефе чын-чынлап бозылды.* С.Рафиков. **Чытык чырайлы** *к.* **чытык йөзле**. *Чытык чырайлы болытлар Каплаган көзнең күгең.* Р.Корбан

**ЧЫТЫКЛАНУ** *ф.* Табигый төсен-кыяфәтен югалту, сытылу, бозылу (йөз тур.). *Окопларга, снаряд ящиклары чокырына, брустверга күз төшергәч, аның йөзе тагын да чытыкланды.* Х.Камалов. *Кояшыңның йөзе чытыкланды.* М.Шиһапов

**Чытыклана бару** Торган саен ныграк чытыклану. *Нисаның чырае чытыкланганнан-чытыклана бара иде.* А.Гыйләҗев

**Чытыклана башлау** Чытыклану билгеләре күренү

**Чытыклана төшү** Бераз чытыклану

**Чытыкланып китү** Көтмәгәндә чытыклану

**Чытыкланып кую** Кинәт кенә чытыклану

**Чытыкланып тору** Хәзерге вакытта чытыклану; вакытлыча чытыклану

**ЧЫТЫКЛЫК** *и.* Йөзе табигый төсен-кыяфәтен югалткан булу, караңгы чырай. *Вагоннарның тәрәзә, ишекләренә тыгылып карап килгән солдатларның йөзләрендә аптыраган сымак көлемсерәү яисә күңелсез чытыклык күренә иде.* Ш.Камал. *Әмма аның йөзендә чытыклык, ачу яки ачыну ярсулыгы сизелми.* И.Салахов

**ЧЫТЫЛУ** *ф. сөйл. к.* **чытыклану**. *Менә хәзер уйлыйм да исем китә: беләсең бит, Фәхри дигәннең тик исемен ишетсәм, йөзем чытыла, тәнем чымырдый, кашларым җыерыла башлый иде.* Г.Ибраһимов. *Ләкин балта осталарының йөзе һаман чытыла, күзләре борчулы гамь пәрдәсе белән томалана бара.* Г.Гыйльманов

**Чытыла бару** Торган саен ныграк чытылу. *Кыз аның йөзе чытыла баруын күрде.* М.Хуҗин. *Тик аның йөзе бизгәктән әрем суы капкандай чытыла бара.* Т.Нурмөхәммәтов

**Чытыла төшү** Бераз чытылу; тагын да ныграк чытылу. *СС офицерларының йөзләре тагын да чытыла төште.* Г.Әпсәләмов. *Минем әрнеп диярлек биргән сорауга дустымның йөзе тагы да чытыла төште.* Р.Кәрами

**Чытылып йөрү** Берара чытылу. *Нәрсәгәдер йөзе чытылып йөри әле: әллә шелтә биргәннәр.* Х.Камалов. *Андый чакта эшеннән бүлдерсәң – кәефе кырыла, теше сызлаган кебек, көн буе чытылып йөри инде ул.* Л.Ихсанова

**Чытылып китү** Кинәт чытылу. *Ришатның йөзе чытылып китте, кечкенә генә борыны бөтенләй җыерчыклар белән капланды.* А.Расих. *Болай да кансыз ак бите чытылып китте: күрәсең, минем керү ошамады – эшен бүлдем.* И.Салахов

**Чытылып куя** Кинәт кенә чытылу. *Таштай каткан йөзе, эчтән нәрсәдер чеметтереп алгандагы кебек, чытылып куйды.* Казан утлары

**ЧЫТЫР** I *и.* **1.** 1) Коры чыбык-чабык, корыган вак ботаклар. *Лапаска тышкы яктан терәп чытыр өеп куелган, шунда ук бүкән өстендә балта ялтырап ята.* Т.Нурмөхәммәтов. *Әхмәтсафаның сүзләре, тәгәрмәчкә уралган чытыр кебек, Җамалның саруын кайнатып кына баралар иде.* Ф.Сафин

2) Тармакланып үскән куе ботаклар, вак-вак ботаклы агач-куаклар. *Аның тирәсендә бик күп чытырлар үскән чакта, аның тирәсен бик тирән упкыннар чолгаган чакта, аның астында коточкыч ярлар, чокырлар казылганда барган юлымыз.* Г.Исхакый

**2.** *с. мәгъ.* Шундый вак ботаклардан ясалган, үрелгән. *Кучәренә күптән дегет тимәгән чытыр арба тавышлары чыгарып, шыгырдый-шыгырдый лифт менде, ишеге ачылды.* Р.Кәрами

**ЧЫТЫР** II *кис. диал.* Сыйфатларның артыклык дәрәҗәсен белдерү өчен кулланыла; бөтенләй, тулаем, гел. *Өстендә чытыр ак куфты белән чем кара юфкы булырые.* Г.Галиева. *Иртәләрен чытыр салкын була, Ә көндезен кояш кыздыра.* Р.Низами

**ЧЫТЫР** III *иярт. диал.* **1.** 1) Берәр нәрсә җиңелчә яки кисәк шартлаганда, сынганда һ.б.ш. вакытта чыккан авазны белдерә. *Чытыр итеп яшен яшьнәү*

2) Нечкә пластик, целлофан һ.б.ш.ны селкеткәндә, бөгәрләгәндә чыккан тавышны белдерә

**2.** *с. мәгъ.* Кыштырдап торган, чытырдаган тавыш чыгара торган. *Уенчыкларны зур чытыр капчыкка салыгыз, алар өстенә сода сибегез.* Сабантуй

**ЧЫТЫРДАП** *рәв.* Бик нык итеп, бик каты (ябышу, күзне йому һ.б.ш. тур.). *Аккүзнең җәрәхәтеннән аккан кызылсу кан үзен дә, аңа чытырдап ябышкан Айдарны да буяп бетерде.* Г.Гыйльманов

**ЧЫТЫРДАТУ** *ф. йокл. юн. к.* **чытырдау**. *Тәрәзәләр зәп-зәңгәр булып каткан, төнге буран, үзенә бер корбан сорагандай, түбәне чытырдата.* М.Мәһдиев

**ЧЫТЫРДАТЫП** *рәв. сөйл.* Бик нык, бик каты, бик нык иттереп. *Кадрия сызланудан күзләрен генә түгел, иреннәрен дә чытырдатып кысты.* В.Имамов. *Зирәк күзләрен чытырдатып йомды.* А.Хәлим

**ЧЫТЫРДА́У** *ф.* Берәр агач нәрсә сынганда, утка су тамганда һ.б.ш. очракларда коры шартлаулы тавыш барлыкка китерү. *Нәрсәләрдер дөбердәп ауды, чытырдап сынды.* Г.Әпсәләмов. *Чытырдап шартлап сынган ботак тавышына башын борырга өлгергән Хәлим каяндыр очып килгән һәм бөтен йөзе белән кереп баткан балта тырпаеп торган кабан гәүдәсенең җирдә бәргәләнеп-тәгәрәп йөрүен генә күреп калды.* Г.Гыйльманов

**Чытырдап алу** Бер тапкыр чытырдау. *Манканың вак ташлы бөртекләре эләккән иде, чәйнәгәндә, ул бөртекләр тешкә эләгеп чытырдап ала иде.* Г.Исхакый. *Тыштагы салкын буранда өй түбәләре чытырдап ала.* М.Мәһдиев

**Чытырдап китү** Кинәт чытырдау. *Йөзләрен күрүгә, бөтен әгъзаларым эсселе-суыклы булып, бөтенләй чытырдап китә.* Г.Камал. *Гимнастёркам чытырдап китте, мөгаен, ертылды.* И.Салахов

**Чытырдап кую** Кинәт кенә чытырдау; бер тапкыр чытырдау. *Янybызда кинәт кенә нәрсәдер чытырдап куйды, һәм күккә яктырткыч ракета очты.* Казан утлары

**Чытырдап тору** Даими чытырдау; хәзерге вакытта чытырдау

**ЧЫТЫРЛЫК** *и. диал. к.* **чытырманлык**. *Чытырлыктан нинди булсаерткыч килеп чыкса нишләрмен?* Л.Хәким. *[Әптерәш:] Чытыр-чытыр чытырман, Чытырлыклы кара урман.* Т.Гыйззәт

**ЧЫТЫРМАН** *и.* **1.** Бик куе булып тармакланып, ботакланып үскән агач-куаклар; куе куаклык; ешлык. – *Нәрсәгә коелып төштең әле, куянйөрәк? – дип, үзен үзе битәрләде Таймас һәм, ярык балтасын уң кулына кысып тоткан килеш, яңадан чытырман арасына керде.* А.Тимергалин. *Менә, ниһаять, чытырман арасына кояш нурлары үтеп керде.* Н.Фәттах

**2.** *с. мәгъ.* Ботаклы-ботаклы, бик нык ботакланып-тармакланып үскән. *Юл кырында нindидер ташландык абзар кебек өй күреп, Нерон атыннан сыдырылып төшә һәм, чытырман куакларны ера-ера, шул өй-абзарга таба мүкәли.* М.Хәбибуллин

◊ **Чытырмандай ябышу** *к.* **чытырман кебек ябышу**. *Ләкин чытырмандай ябышкан таш кына түзмәде, ишелеп төште.* М.Әмирхан. **Чытырман (кебек) ябышу** Бик нык тотыну, ябышу, бәйләнү. **Чытырман кул** Эләктерсә җибәрми торган көчле, нык кул. *Ире артыннан күзәтеп торган Шәмсегаян, яратмыйча, башын чайкады: – Ертып ук чыгардың... Кулың каты шул синең, чытырман кул, тотсаң – өзәсең...* А.Гыйләҗев

**ЧЫТЫРМАНЛАНУ** *ф.* 1) Агач-куаклар ботакланып, тармакланып, чытырманлык барлыкка китерү. *Су буенда – чытырманланып үскән яшь таллык.* М.Хәсәнов

2) *күч.* Чуалып, уралып куелык барлыкка китерү. *Кадермәтев, чытырманланып үскән сары мыегын кабартып, эре генә әйтте.* К.Нәҗми

**ЧЫТЫРМАНЛЫ** *с.* Чытырман барлыкка китергән, агач-куаклар ботакланып, тармакланып үскән. *Ә һәр сафка йөзәр-йөзәр булып баскан унөч мең җайдак чытырманлы тау итәгенә*

*килеп тезелде дә Тимучин әмерен көтә башлады.* В.Имамов. *Нигә үз елгабыз Мишә буйлап гизмәскә һәм чытырманлы урманыбызны аркылыга-буйга узмаска да, нигә күрше-тирә авылларны йөреп чыкмаска икән?!* М.Хуҗин

**ЧЫТЫРМАНЛЫК** *и.* 1) Чытырманлы урын, агачлар һәм куаклар бик куе булып, ботакланып-тармакланып үскән урын. *Акъял читкә тайпылып капылт сикерде дә, уңны-сулны абайламый, алга – куе чытырманлык эченә томырылды.* В.Имамов. *Куе чытырманлык, ауган агачлар аларның юлларына киртә булсалар да, Нурсилә дә, Баһадәр дә арымадылар, талчыкмадылар.* А.Нәҗми

2) *күч.* Нинди дә булса катлаулы яисә авыр аңлаешлы нәрсә турында

**ЧЫТЫРТ** *иярт.* Корыган ботак сынганда, яшен яшьнәгәндә һ.б.ш. очраклардан барлыкка килгән кыска өзек тавышны белдерә. *Кинәт чытырт итеп яшен яшьнәде.* Л.Лерон

**ЧЫТЫ́РТ-ЧЫТЫРТ** *иярт.* Кисәк һәм өзек-өзек чытырдау тавышларын белдерә. *Кыз, былтырдан калып кипкән үлән сабакларын ерып, алга атлады, аяк асты баскан саен чытырт-чытырт килде.* Казан утлары

**ЧЫТЫ́Р-ЧАТЫР** *җый. и.* Корыган чыбык-чабык, корыган ботаклар. *Торымтай, Тотышны иңбашына салып, нииндидер чытыр-чатыр арасыннан, нииндидер кәҗә сукмагыннан иплән кенә, сакланып кына су янына ук төште.* Н.Фәттах. *Аяк астында чытыр-чатыр сынган ботак тавышлары ерагая.* Т.Мөбарәков

**ЧЫТЫ́Р-ЧЫТЫР** *иярт.* Нәрсәләрдер сынгаланганда, кат-кат яшен яшьнәгәндә һ.б.ш. очракларда барлыкка килгән тавышны белдерә. *Тәүлекнең калган өлеше кар өстендә чытыр-чытыр янган учак янында ашарга әзерләп, ботка өлгергәнне көтеп, палатка тирәсендә таптанып һәм аның эчендә кырын ятып уза.* А.Хәсәнов. *Әнә каршыда чытыр-чытыр чыра яна, идән уртасындагы учакта нидер пешә.* Ф.Бәйрәмова

**ЧЫЧЫЛДА́У** *ф. сөйл.* [с] авазы урынына [ч] авазы куллану, [ч] авазы кулланып сөйләшү. *Алар ягында Санияне Чания дип чычылдап сөйләшәләр*

**ЧЫШИ́-ПЫШИ** *иярт. сөйл. к.* **чыш-пыш**. *Иске чиркәү тирәсендә, караңгы агачлар арасында, гүя әллә нинди пәриләр яшеренгән, качынган, үзара чыши-пыши киңәшкән, күз кысышкан кебек булалар.* Ш.Камал

**ЧЫ́Ш-ПЫШ** *иярт.* **1.** 1) Чи утын янганда, пар бөркелеп чыкканда һ.б.ш. очракларда барлыкка килгән тавышны белдерә. *– Чи усак утынымдай чыш-пыш пыскып ятканчы, олуг ялкында янып бетүең мең кәррә артык, – диде туташ.* Р.Батулла

2) Ишетелер-ишетелмәс сөйләшкәндә чыккан тавышны белдерә

**2.** *рәв. мәгъ.* Ишетелер-ишетелмәс, пышылдап, тавыш чыгармыйча диярлек. *Гөлтуташ белән Зифа кичләрен өйалдына чыгып кына чыш-пыш елашалар.* В.Имамов

**3.** *с. мәгъ.* Ишетелер-ишетелмәс, пышылдаган. *Сәндерә ягыннан тиенкы көлү, чыш-пыш тавышлар ишетелде.* Ф.Сафин

**4.** *и. мәгъ.* Сер итеп колактан колакка сөйләнә торган сүз-хәбәр. *Халык арасында да чыш-пыш китте.* Г.Әдһәмова. *Коллектив башлыча хатын-кызлардан гына торганга, гайбәт, имеш-мимеш, чыш-пыш та бик тиз тарала.* И.Нәбиуллина

◊ **Чыш-пыш килү** Бик акрын гына, ишетелер-ишетелмәс сөйләү, сөйләшү; пышылдау. *Казан урамнары чыш-пыш килгән хәбәр белән тулды.* В.Имамов. *Укучылар чыш-пыш килеп сөйләшә башладылар.* И.Диндаров

**ЧЫШТЫ́Н-ПЫШТЫН** *рәв. к.* **чышын-пышын**. *Заһири Харисовны беренче тапкыр күрүдә: – Әкәмәт төсле кешеләр була икән дөньяда, – дип, хатынына чыштын-пыштын гына сөйләп узып киткән иде.* Г.Толымбай. *Инде үсеп җиткәч тә, әти-әнисенең өйләрендә дә, урамда да үзара һаман чыштын-пыштын рәхәтләнеп үз телләрендә аралашып йөрүенә карамастан, кызлары «рус милләте» дип язылган паспорт алган.* Н.Гариф

**ЧЫШТЫРДА́У** *ф.* Чыштыр-чыштыр килү, чыштыр-чыштыр итү. *Урман ачыла, Аяк астында Яфрак кыштырдый, Яфрак чыштырдый.* Ш.Галиев. *Кайдадыр, тынлыкны сискәндереп, майламаган ишек шыгырдый, галуш чыштырдый, нидер укынган авазлар ишетелеп кала, комган шалтырый...* А.Гыйләҗев

**ЧЫШТЫ́Р-ПЫШТЫР** *иярт.* **1.** Кәгазьләр, коры яфраклар һ.б.ш. берберсенә ышкылганда чыккан саңгырау тавышны белдерә. *Арттан килүче һаман йөгерә, үзе узып та китми. Кыштыр-кыштыр, чыштыр-пыштыр, кыштыр-кыштыр.* М.Садыйков

**2.** *рәв. мәгъ. к.* **чышын-пышын**. *Берзаман болар чыштыр-пыштыр йөриләр.* Сөембикә

**ЧЫШТЫ́Р-ЧЫШТЫР** *иярт.* Вак таш өстеннән барганда, тукымалар, кәгазьләр кебек нәрсәләр ышкылганда һ.б.ш. очракларда барлыкка килгән тавышны белдерә. *Эчке якта кемнеңдер чыштыр-чыштыр, шыгыр-шыгыр килеп киенеп мәшәкатьләнгәне ишетелде.* А.Хәлим. *Галошларын чыштыр-чыштыр сөйрәтеп ишегалдына кергән карчыкны мин танымадым.* Н.Гыйматдинова

**ЧЫ́Ш-ЧЫШ** *иярт.* Агачны ышкылаганда, идән себергәндә һ.б.ш. вакытта барлыкка килгән тавышны белдерә. *Күрше бүлмәдә асрауның чыш-чыш кына, акрын гына идән себерүе ишетелеп, Фазыл әфәнденең әллә кайвакытларын искә төшерә иде.* Г.Исхакый. *Юлдан ерак та түгел берәү чыш-чыш агач кисеп ята.* В.Нуруллин

**ЧЫШЫЛДА́У** *ф.* Куыш, көпшә морҗа кебекләрдән ургылып пар, һава чыкканда һ.б.ш. очракларда сызгыру кебек тавыш барлыкка килү. *Чөнки ул сүзләрне кабатлауның бер мәгънәсе дә юк, су кранына да тәэсир итмәде алар: чышылдады, ысылдады да кран, калтыранып алгач, бер тамчы күгәрек су төкерде.* Идел

**ЧЫШЫ́Н-ПЫШЫН** *рәв. сөйл. к.* **чыш-пыш 2.** *– Чит җирдә дә үзебезнең дин-иманнан аерылмаган өчен Аллаһы рәхмәте бу, – дип, кайберәүләр чышын-пышын гына сөенеч белдерергә дә ашыкты.* В.Имамов. *Ләкин шагыйрь үзе исән-имин әйләнеп кайтканчы, ул аның шигырьләрен чышын-пышын гына сөйли иде.* М.Хуҗин

◊ **Чышын-пышын килү** *к.* **чыш-пыш килү**. *Әллә нишләп егетләр, чышын-пышын гына килеп, тавышларын басып сөйләштеләр.* В.Имамов. *Бөтенесе чышын-пышын килә, тегендәмонда йөгерешә, анысын-монысын котырта, тик Рафия генә болардан бихәбәр.* Р.Рахман

**ЧЫЮ** *ф. диал.* Очлы әйбер белән тырнап язу, сызык төшерү. *Кабер ташына чыеп язу*

# Ш

**ШАБ** *и. гар.* Ачуташ, яра ташы; *русчасы:* **квасцы**

**ШАБАЛА** *и.* 1) Сука яки сабан төрәненә ябышкан туфракны кырып төшерү өчен махсус таяк; туфрак ябышмас өчен төрән алдына куела торган таяк; сука калагы. --- *[Фәридә] сабанга якынрак килде, берни эндәшмичә көрәгенә тотынды һәм әкрен генә, салмак кына кыланып, төрән шабалаларын чистартырга кереште.* Н.Фәттах

2) Аш бүлү чүмече // Тишекле чүмеч

3) *диал.* Кашык

**ШАБАЛАБОРЫН** *и. диал.* Үрдәкнең бер төре; *русчасы:* **утка-соксун**

**ШАБАШ** *и. яһүд сөйл.* **1.** 1) Эш тәмамлангач, сирәгрәк – бер өлеше беткәч ясала торган ял, тәнәфес, тын алу өчен аралык. *Адым саен боцман акырына, шулай да шабаш ясыйсың, ярга чыгасың.* А.Таһиров. *Ихсан, кич берлә шабаш бирелгәч, урынына ятты.* Ак юл

2) *к.* **шабашка**. *Бер урында торып эшләмәдем монда. Шабашка чыккаладым.* М.Хуҗин. --- *авылның тырыш ир-егетләре тормыш алып бара, йорт җиткерә, баласын укыта. Элегрәк язҗәй айлары гына «шабаш сезоны» дип йөртелсә, хәзер исә ел дәвамында эшсез ятмаска була.* Г.Сафина

**2.** *хәб. мәгъ.* 1) Бетте, тәмам. *Ардагы микроблар. Синә сиздермичә генә эчтән кимерә-кимерә киләләр дә бервакыт кинәт кенә сине операция өстәленә салдырталар. Үкенергә дә өлгермисең – шабаш!* М.Мәһдиев. *Кичкырын яңа кишәрлеккә тотынмыйбыз инде, бүгенгә шабаш*

2) Эш начар, яман. *Ничек тә бертөрле карарга килә алмый йөди кебек иде. Болай итсәң дә шабаш, тегеләй итсәң дә шабаш килеп чыга.* Х.Камалов. *Болай булгач, синең эшләр шабаш*

**3.** *ы. мәгъ.* Борчылу, эчне пошырган нәрсәгә ачу килү, чарасызлыктан аптырау һ.б.ш.ны белдерә; берни эшләп булмый, бетте-китте, вәссәлам. --- *мин беләм: хәрәмсез түгел бу эш. Яхшылап әйткәнне аңламый икән, утыртам мин аны. Шабаш.* Т.Гыйззәт. *Нинди чокыр, кайдан килгән чокыр – һич белмим, аңламыйм, шабаш!* Ә.Еники

◊ **Шабашка калу** *иск.* Комиссия тарафыннан хәрби хезмәткә яраксыз дип табылу. *Ул әниләренә, якын карендәшләренә Садыйкның бүген каралмавын, Садыйкның иртәгә соң гына каралуын, аның шабашка калуы бик ихтималлыгы хәбәрен китерде.* Г.Исхакый

**ШАБА́ШКА** *и. сөйл.* 1) *тар.* Совет чорында рәсми рәвештә билгеле колхоз, оешма яки предприятиедә эшләмичә, берәр кәсеп белән (балта эше, төзүчелек һ.б.ш.) үз кесәсенә акча эшләү күренеше, шулай көн күрү рәвеше, акча эшләү юлы. --- *аларның да ирләре колхозда «таяк»ка бил бөкми, шабашкада йөреп акча көри иде.* Н.Гыйматдинова. *Тәгаен колхоз эшен ташлап, берәр җиргә шабашкага таюы.* В.Нуриев

2) Шул рәвешле башкарыла торган эш. *Җәен – шабашкада эшләп, бөтен тирә-юнь белән танышып, кышын кибет басарга йөрергә өйрәнеп киткән икән алар.* Н.Акмал. *Беркөнне, шабашкасын төгәлләп, әтисе кайтты.* Н.Гыйматдинова

3) Хезмәткәрнең төп эшеннән тыш, гадәттә, үзенең буш вакытында башкарыла торган өстәмә эш. *Син шабашка эзләп йөрүче студент түгелмени?* З.Хәким. *Дөрес, мин акча табармын, елларда шабашкада эшләргә була, мөгаен, сине ач ук итмәмдер...* Р.Зарипов

4) Чит эш эшләп, гадәттә, тиз арада алынган өстәмә табыш, керем. *Рәфкать, күрәсеңме, бүген синең кесәңә көтмәгән җирдән умырылып шабашка керергә тора бит.* А.Хәсәнов. *Заводта күпме алганны беләсең, шабашканы да тиенenә кадәр апкайтып тоттырам.* А.Әхмәтгалиева

5) *куч.* Үтә сыйфатсыз, аннан-моннан, бары тик файда алу өчен генә башкарылган эш, тудырылган әсәр. *Үзе художник, тегендә-монда «шабашка» ясап, кырык җиденче ел реформасына кадәрге бәрәкәтсез акчаны көрәп ала – мең данәле «Волна» папиросын чыгарып өстәлгә салу моның өчен теш арасыннан черт итеп өч метр ераклыкка төкерү белән бер.* М.Мәһдиев. *Көндәлек матбугат битләрен тезмә һәм чәчмә халтура, шабашка юморы басып китте.* Р.Миңнуллин

**ШАБАШЛА́У** *ф. сөйл.* 1) Эштән туктап тору, тәнәфес ясау, ял итү. *Корабль тау-тау булып килгән дулкынга каршы күкрәген киереп бара. Сәгатенә егерме биш шабашлый.* А.Таһиров

2) Эшне тәмамлау, тәмамлап эштән туктау

**ШАБАШЛЫК** *и. сөйл. к.* **шабашчылык**. *– Калае тимердән дигәндәй булса да, егетләрнең кулы алтын, – дип бәяләде ул әлеге дүрт шабашчының ярты көнлек эшен. – Иҗат итә беләләр. Шабашлык – аларның төп кәсебе.* М.Хуҗин. *Инәкәй, бер мәзәк кенә сөйлим әле. Без тегендә шабашлыкта йөргәндә көн кыскарта идек шулай.* М.Мәһдиев

**ШАБА́ШНИК** *и. рус сөйл.* 1) *к.* **шабашчы**. *Агач әзерлиләр, диме? Әллә шулар белән генә сөйләшеп карарга инде? Шабашниклар, ди, бит, бер бура гына килештереп булыр әле.* Г.Гыйльманов. *Әле кыш көне генә ике егетебез бар иде. Берсе, җылы яктан очып килгән шабашникларга ияреп, озын берлек артыннан чыгып китте.* К.Кәримов

2) Эшне сыйфатсыз башкарып, акча, табыш өчен генә эшләүче, җиңел кәсеп яратучы кеше. *Халыкның башын Кашпировскийлар әйләндергәнче үк әле, нindider шабашник-күзбуар безнең авыл клубларында гипноз сеансы үткәреп йөри икән.* М.Вәлиев. *Электән үк татарча эшләүче шабашник артистлар бар инде.* Безнең гәҗит

**ШАБА́ШНИКЛЫК** *и. сөйл. к.* **шабашчылык**. *Ире Исмәгыйль берничә атна шабашниклыкта йөреп, кесәләрен акча белән тутырып кайта да өч көн айнымастан эчә.* Ф.Яруллин. *Төзелеш академиясенә кердегез, һәм менә сезнең тыйнаклыгыгыз сезне безнең белән бергә шабашниклык итәргә алып килде.* Т.Миңнуллин

**ШАБАШЧЫ** *и. сөйл.* Шабашка белән көн күрүче кеше, шабашка белән шөгыльләнүче кеше. *Колхозчылар ялкауланса, ниләр булгай, Балта тотып шабашчылар килеп тулгай, Ферма төзеп бирәбез без алай-болай, Акчаны шәп түләсәгез, дияр имди.* Г.Афзал. *Ул*

*җәйдә дә өченче ел рәттән кумхуҗ фермалары төзелешендә шабашчы әрмәннәр бил бөктеләр.* Ф.Яхин

**ШАБАШЧЫЛЫК** *и. сөйл.* Шабашка белән көн күрү рәвеше, шабашка шөгыле. *Монысы шабашчылык саналадырмы – тәгаенли алмыйм.* М.Хуҗин

**ШАБДАР** *и. фар. бот. к.* **тукранбаш**

**ША́БЕР** *и. нем. тех.* 1) Металл өслекләрне тигезләү, шомарту, литография һәм гравировка эшендә кырып сурәт төшерү өчен үткен кырлары булган корыч кендектән гыйбарәт кискеч инструмент

2) Шундый эшләрне механик юл белән эшләү өчен электрлы кул машинкасы

**ША́БЕРЛАУ** *ф.* Шабер белән эшкәртү, кыру

**ШАБЛИ** *и. фр.* Йөземнең бер сорты. *Шабли үстерү* // Ак коры шәраб сорты. *Шаблиның үзенчәлекләре* // Шундый сортлы шәраб. *Шабли эчү*

**ШАБЛОН** *и. нем.* **1.** 1) Бер үк зурлыктагы һәм формадагы эшләнмәләрне ясау өчен калып, өлге. *Ихтимал, таш уючы осталар бер төрле үрнәк-шаблоннар куллангандыр.* Безнең мирас. *Башта шаблон төшереп киссәләр, хәзер эшне автомат башкара икән.* Акчарлак

2) Әзер эшләнмәләрнең зурлыгы һәм формасы дөрес булуын, үлчәмнәргә туры килүен тикшерү өчен махсус инструмент, җайланма. *[Цехта] Йомры башлы, очлы койрыклы Тамчы сыман хикмәт чүкиләр, Тимер шаблон белән үлчиләр.* Г.Афзал. *Монда эшнең очыкырые юк: буровойларга торбалар, обсадкалар, турбобурлар һәм бораулар ташыйбыз, заводтан килгән торбаларны эстакадага тезәбез, нечкә насос-компрессор торбаларын шаблон белән тикшерәбез.* Ә.Салах

3) *күч.* Берәр өлкәдә кабул ителгән үрнәк, нигез итеп алынган форма, ысул һ.б.ш. *Без, гадәттә, исем-фамилияләребезне русча шаблонга буйсынып язабыз.* М.Госманов. *Партия җыелышлары, мәсәлән, язып куелган шаблон буенча ачылырга тиеш иде ---.* Т.Миңнуллин

4) *күч.* Уйлап тормыйча, механик рәвештә иярелә торган әзер үрнәк; трафарет, штамп; еш кулланылган, бер үк төрле, яңалыгы булмаган эш итү ысулы. *Немецлар бу юлы да үз кагыйдәләрен тотарлармы? Аларда да шаблонга табыну бик көчле. Гадәттәгечә эшләргә тиешләр.* Х.Камалов. --- *Тукай дөнья поэзиясендә булган барлык алымнардан да иҗади файдаланырга омтыла. Катып калган трафаретларны, шаблоннарны кабул итми.* Т.Галиуллин

**2.** *с. мәгъ.* 1) Билгеле шаблон **1.** (*1 мәгъ.*) нигезендә эшләнгән. *Бәлки, без яшәгән шаблон тартмалар, аларның шыксызлыгы безнең бер-беребезгә кыласы мәрхәмәтлелекне җуеп бетергәндер, дигән уйлар килә Венециядә йөргәндә.* М.Юныс

2) Алдан билгеләнгән, төгәл схема рәвешендәге, әзер калыптагы. *Шуңа күрә урманчы турында язылган теләсә кайсы мәкалә «...үз вазифаларына намуслы карый», «...производство планнарын даими үтәп бара» ише шаблон характеристиканы хәтерләтә.* Татарстан яшьләре

3) Гадәти, яңалыгы булмаган, үзгәрешсез, бертөрле, катып калган. *Нинди шаблон теманы нинди матур шигырьгә әверә ала.* Х.Туфан. *Юк, игенгә тир таммый. Аңа көч, энергия, ярату, хезмәт дәрте сарыф ителә. Теге шаблон җөмләне мин яратмыйм...* М.Мәһдиев

**ШАБЛОНЛАШТЫРУ** *ф.* Билгеле шаблонга (*3 мәгъ.*) буйсындыру, схемалаштыру, калыплаштыру, бердәйләштерү. *Роберт Әхмәтҗановның иҗатындагы кошлар тематикасының (махсус шаблонлаштырып әйттем) ачкычы, бәлки, менә шушы шигырьдәдер (сиксән өченче бит): «Бу ояда сиңа да канат чыгар тиздән Ничек сине сакларга, тидермичә ятлардан?»* М.Юныс

**Шаблонлаштыра башлау** Шаблонлаштырырга тотыну

**Шаблонлаштыра төшү** Бераз шаблонлаштыру, тагын да ныграк шаблонлаштыру

**Шаблонлаштырып бетерү** Тәмам шаблонлаштыру, нык шаблонлаштыру

**Шаблонлаштырып җибәрү** Артык шаблонлаштыру

**ШАБЛОНЛАШУ** *ф.* Билгеле кысаларда катып калу, шаблонга (2 мәгъ.) әйләнү, шаблон булып китү. *Әдәби әсәрне аңлау һәм аңлатуда кайбер тәнкыйтьчеләр күптән тапталган, шаблонлашкан схемалар белән эш итәргә яраталар.* А.Гыйләҗев. *Исәнләшү ситуациясендә әйтелә торган хәл сорау җөмләләре дә шаблонлашканнар һәм сөйләмнең милли үзенчәлеге булып киткәннәр.* Р.Абдуллина

**Шаблонлаша башлау** Шаблонлашуга табан үзгәрү

**Шаблонлаша төшү** Бераз шаблонлашу, тагын да шаблонлашу

**Шаблонлашып бетү** Тәмам шаблонлашу

**Шаблонлашып китү** Тора-бара шаблонлашу

**ШАБЛОНЛЫ** *с.* **1.** 1) Шаблон белән, шаблон нигезендә эшләнә, ясала торган. *Гади шаблонлы сайтлар инде күптән кешеләрне җәлеп итә алмый.* Д.Сәфәров

2) Шаблонга (*2 мәгъ.*) буйсындырылган, иҗади булмаган, гадәти алымнар белән эшләнгән

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Шаблон (*1 мәгъ.*) ярдәмендә, шуны кулланып

2) Урнашкан фикергә ияреп, кысалардан чыга алмыйча, иске алымнар белән. *[Гадиләштерүчелек] ул шул зур фикернең зурлыкларына зарар китерер дәрәҗәдә шаблонлы язуда.* Һ.Такташ

**ШАБЛОНЛЫК** *и.* **1.** Шаблон (*1 мәгъ.*) ясау өчен кирәк булган, шуңа дип әзерләнгән материал. *Әйбәт шаблонлык эзләү*

**2.** *с. мәгъ.* Шаблон (*1 мәгъ.*) ясау өчен кирәк булган, шуңа дип әзерләнгән, шуңа яраклы, шуңа җитәрлек. *Шаблонлык фанер*

**ШАБЛОНЛЫЛЫК** *и.* Шаблонлы булу, штампларга, үрнәкләргә иярү күренеше; формальлек, схемалылык. *Эшчәнлеге дәверендә гел иҗади эзләнүдә булды, шаблонлылыкны, искелекне, формальлекне ихлас күңеле белән кабул итмәде, өнәмәде.* Балтач энциклопедиясе

**ШАБЛОНСЫЗ** *с.* **1.** Шаблоны (*1 мәгъ.*) булмаган; шаблон кулланылмаган

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Шаблон (*1 мәгъ.*) кулланылмыйча

2) *күч.* Яңача, үрнәккә иярмичә, иҗади, мөстәкыйль рәвештә. --- *матбугат аша пропаганда алып барганда, тормыш һәм үзебезнең чынбарлык фактларыннан ачык итеп, шаблонсыз файдалана белергә кирәк ---.* М.Вәлиев

**ШАБЛОНСЫЗЛЫК** *и.* Шаблоннардан азат булу, шаблонсыз эш итү күренеше; иҗадилык. *Бүгенге чынбарлыкны әдәбият күренешенә әверелдерү чиктән тыш авыр, чиктән тыш катлаулы. Көн тәртибендә – плюрализм, шаблонсызлык.* М.Юныс

**ШАБЛОНЧЫ** *и.* 1) Шаблон (*1 мәгъ.*), әзер өлге ясаучы

2) *күч.* Шаблон (*3 мәгъ.*) белән эш итүче, шаблонга иярүче; мөстәкыйль, иҗади уйлап түгел, ияреп фикер йөртүче

**ШАБЛОНЧЫЛЫК** *и.* Шаблоннарга (*3 мәгъ.*) иярү; мөстәкыйльлек, иҗади фикер җитмәү күренеше. *Әдәбиятыбызның бай үткәнен, бу рәвешчә, социологик яктан гына карап, сәяси*

*чорларга бүлүне шаблончылык дип бәяли [Вәлиди].* Ф.Галимуллин

**ШАБРО́ВКА** *и. рус* Металл (сирәгрәк – агач һәм пластик) өслекләрне махсус инструмент – шабер ярдәмендә югары төгәллек белән тигезләү, шомарту технологиясе

**ШАБРО́ВКАЛАУ** *ф.* Шабер белән эшкәртү, шабровка эшен башкару

**ША́БЫР** *кис.* Тирләү турында сүз барганда интенсивлык төсмере өсти; манма, лычма. *Район күләмендәге киңәшмәләрдә булсын, райком бюросында булсын, башкалар шикелле шабыр тиргә батып, тын алырга да куркып утырмый.* В.Нуруллин. *Тау менеп җиткәндә, малай шабыр тиргә батты, хәтта тез буыннары калтырый башлады.* А.Тимергалин

**ШАБЫРДАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **шабырдау**. *Унбиш-егерме минут дигәндә, Фәнүзә барлык керләрне сабынлады да, чиләккә шабырдатып су агызганнан соң, иелеп-бөгелеп, үрмәлимүкәйли идән юарга кереште.* Ә.Баян. *Әнисә исә, баланы диванга утыртып, аяк киемнәрен салдырды да чәйнекне утка куйды, шабырдатып ваннага су җибәрде.* М.Маликова

2) Берәр эш-гамәлне бик тиз, бердәм, туктаусыз үтәү. *Хәзер генә ул зыялылыкның (һәм джентльменлыкның) нәрсә икәнен аңламаган әдипләр, үз әсәрләрен тәнкыйть иткән автор шәһәр урамында очраганда, юлларын үзгәртәләр, урманда очраганда, шабырдатып куак арасына кереп калалар...* М.Мәһдиев

**Шабырдата башлау** Шабырдатырга тотыну

**Шабырдатып алу** Аз гына, тиз генә шабырдату

**Шабырдатып җибәрү** Кинәт шабырдата башлау

**Шабырдатып кую** Бер тапкыр шабырдату

**Шабырдатып тору** Өзлексез, туктаусыз шабырдату, әле хәзер шабырдату

**ШАБЫРДА́У** *ф.* 1) Берәр каты яңгыравык өслеккә коры, эре бөртекле, төерле сибелүчән масса коелып яки эре тамчылар төшеп, шабыр-шобыр иткән тавыш чыгару. *Кояшлы көннәр иде, челтәрләнеп, уалып карлар эри, түбәләрдән, шабырдап, тамчылар коела.* Ә.Еники

2) Көчле агым булып, зур басым белән, шаулап агу, гөжләү

3) Сыеклык яки коры, сибелүчән нәрсәләр күпләп, мул итеп сибелү, түгелү, коелу. *Ә безнекеләр кранны бөтен көченә ачып куялар да, су шабырдап агып тора.* Шәһри Казан

4) Коры яфрак, каты үлән һ.б.ш. селкенгәндә кыштырдау, шавылдау. *Шабырдатып миләш яфракларын, Салкын җилләр исеп үттеләр.* Ф.Алимов

5) Күпләп бүленеп чыгу. *Күз яшьләре шабырдап түгеләме, әллә сабынлы кара сумы – белүе дә кыен иде.* Ә.Баян. *Торып кайнар кояш астына чыгам, балта алып авыр түмәрләрне ярам! Эссе дә онытыла, шабырдап тир ага, йөрәккә дә рәхәт.* Ш.Галиев

6) Артык күп сөйләү, лыгырдау // Урынсыз, кирәксез нәрсәләр сөйләү, ялгыш сөйләп ташлау

**Шабырдап алу** Аз гына, тиз генә шабырдау

**Шабырдап йөрү** Озак вакыт, гел, теләсә кайчан һәм теләсә кайда шабырдау

**Шабырдап кую** Кисәк, бер мәртәбә шабырдау

**Шабырдап тору** Бертуктаусыз шабырдау; хәзерге моментта шабырдау

**Шабырдый башлау** Шабырдарга тотыну

**ШАБЫРДАШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **шабырдау**. *Бер якта йомшак кына искән җилдә дә, сүзләре бетмәс ахирәтләр кебек, шабырдашып ак каусәле усаклар утыра.* М.Хәсәнов

2) Күп кеше берьюлы кыштырдаган, пышылдап сөйләшкән һ.б.ш. тавышлар чыгару. *Сыйныф беравык тыныч торды да, кинәт шабырдаша, чыш-пыш сөйләшә башлады.* М.Әхмәтшина

**Шабырдаша башлау** Шабырдашырга тотыну

**Шабырдашып тору** Бертуктаусыз шабырдашу; хәзерге моментта шабырдашу

**ШАБЫ́Р-ШАБЫР** *иярт. к.* **шабыр-шобыр**. *Тәҗрибәле күзле Сакманов, каршыга ыргылган машинаның алар ягындагы кузовының ачыклыгын һәм аннан, шабыр-шабыр килеп, төрле авазлар чыгарып, нәрсәләрнеңдер асфальтка, җиргә тәгәрәп-мәтәлеп төшүләрен шәйләп алды.* Т.Галиуллин. *Мөдир «Кайрыгызны алмыйм, шабыр-шабыр ком коела бит, егетләр», – дип киреләнә, үлчәүдән бәйләмнәрне читкә томыра.* Р.Әбделмәнов

**ШАБЫ́Р-ШОБЫР** *иярт.* 1) Яңгыр яуганда, су югарыдан түгелгәндә, көчле чәчрәгәндә, эре тамчылар яки бөртекле нәрсәләр каты яңгыравык өслеккә төшеп барлыкка китергән тавышны белдерә. *Ана белән нәнә, аның шабыр-шобыр юынганын тыңлап, елмаешып шатлык кичерделәр.* Ә.Баян. *Көзге яңгырның салкын тамчылары шабыр-шобыр тәрәзә калаена бәрелде.* М.Яһудин

2) Коры яфрак, каты үлән һ.б.ш. селкенгәндә кыштырдаган, шавылдаган тавышны белдерә. *Коры, җылы җил урамдагы әле бар агачка, әле икенчесенә бәйләнеп шабыр-шобыр яфрак коя иде.* М.Мәһдиев

3) *күч.* Сыеклыкның, сибелүчән нәрсәләрнең күпләп, мул итеп сибелү, түгелү рәвешен белдерә. *Акча түләп яллаганмыни, түшен киереп баскан да Бикташтан бакчаларына безнең мичкәдән шабыр-шобыр су сиптертә!* М.Маликова. *Әле монда, әле тегендә чәрдәкләнгән нарат ботаклары сыгылып төшә, өлгерә башлаган күркәләр шабыр-шобыр җиргә коела.* З.Мәхмүди

4) *күч.* Берәр югарырак урыннан, транспорттан һ.б.ш. җирдән тиз-тиз, берәм-берәм төшү, нәрсәнеңдер күпләп коелу рәвешен белдерә. *Күп булса, ярты сәгать эчендә – Казан. Тукталды поезд. Һәм балалар шабыр-шобыр коелырга керештеләр.* Ә.Баян. *Әле монда, әле тегендә чәрдәкләнгән нарат ботаклары сыгылып төшә, өлгерә башлаган күркәләр шабыр-шобыр җиргә коела.* З.Мәхмүди

**ШАВА** *и. диал.* 1) Чокып ясалган зур агач табак. *Иң элек ул аңа тезенә хәтле үк төшеп торган ак күлмәк белән иләмсез киң ак ыштан кидерә, шулар өстеннән яшел-сары буйлы ефәк чапан кидерә, ә башына егерме аршин ак бәздән, Бохара түбәтәе тирәли, шавадан да зуррак чалма урап куя.* Ә.Еники

2) Гомумән зур табак. *Шавада камыр басу*

**ШАВЫЛ** *иярт.* **1.** 1) Урман, яфрак, куе үлән һ.б.ш. җилдә селкенгәндә чыгарган көчле тоташ шауны белдерә. *Шавыл да гына шавыл ни шавылдый – Агыйделкәйләрнең камышы.* Җыр

2) Шәһәр, механизмнар, кешеләр массасы һ.б.ш. чыгарган тоташ тавышны, гөрелтене белдерә

**2.** *и. мәгъ.* Шау, гөрелте, шаулаган тавыш. *Диңгез өсте шавыл; Диңгез өсте ярсу. Ачу сөйләп үтте дулкыннар. Сакчы Моратның да йөрәгендә Шавыл күтәрелде.* Н.Исәнбәт

**ШАВЫЛДАТУ** *ф. йөкл. юн. к.* **шавылдау**. *Әкрен генә бер татлы җил исеп китә, Ялтыраган күлнең битен шадралата. Барып җитә томрап*

*торган урманнарга, Назлап, сөеп яфракларын шавылдата.* Г.Сөнгати

**ШАВЫЛДА́У** *ф.* 1) Көчле җил, басым һ.б.ш. тәэсирендә селкенеп тоташ шау барлыкка китерү, шаулау. *Агыйделкәйнең камышы, Шавылдыйдыр җилдә, давылда.* Бәет. *Анда урманнар шавылдый катфәдәй яфрак белән, Аңкый хуш ис чәчкәләрдән, анда матур, җәйге ямь.* Г.Сөнгати

2) Гөрләү, көчле агым белән аккан, кайнаган һ.б.ш. су шаулау. *Килеп җитә сөйкемле язгы көннәр, Матур, саф, тын һавалы, ямьле төннәр. Ага башлый шавылдап су урамнан, Арына бозларыннан елга-күлләр.* К.Хаммадов

3) Бик көчле басым белән агу, көчле агым хасил итү; кайнап тору. *Сез пароход барган вакытта артыннан калган дулкыннарын күргәнсездер. Менә шавылдап, күбекләнеп бер дулкын чыкты.* К.Нәҗми

4) Гөжләү, гүләү, тавышлану, шаулашу. *Шавылдап кычкыра шул чакта тауда төнге мәхлуклар.* М.Гафури. *Урман сыман шавылдаган халык ул сәхнәгә менгәч басылды.* Н.Гыйматдинова

**ШАВЫЛДАШУ** *ф. урт. юн. к.* **шавылдау**. *Шау-шу шау камыш Шавылдашып бара имеш. Утыз ике йомырка оясында кала имеш.* Табышмак

**ШАВЫЛТЫ** *и.* Шау, гүләү, шаулау тавышы. *Вагонның түбә тимеренә сибелеп торган яңгыр бөртекләреннән йомшак кына шавылты ишетелеп, гүяки кайдадыр шыпырт кына киңәшләшү барган шикелле тоела ---.* Ш.Камал

**ШАГРЕНЬ** *и. рус<төрки* **1.** 1) Элек ат тиресенең сырт турысыннан, соңрак сарык, кәҗә (аерым бер төре акула яки скат) тиресеннән эшләнә торган, өстендә бөртек-бөртек кытыршылары булган югары сыйфатлы күн төре. *Махсус эшкәртелгән акула тиресеннән – шагреньнан – искиткеч эшләнмәләр ясыйлар.* Биология

2) Шундый күнгә охшаган кытыршы өслек

**2.** *с. мәгъ.* Шул күннән эшләнгән

**ШАГЫЙЛЬ** *и. гар. иск.* Шөгыльләнүче, мәшгуль кеше. *Ничек диләр? Сине «шагыйрь» диләрме? Шигырь язмак белән шагыйль диләрме?* Г.Тукай

**ШАГЫ́ЙРАНӘ** *рәв. гар-фар.* **1.** 1) Шагыйрьләрчә, шагыйрьләр кебек. *Бу дөньяга шагыйранә карап Яши алмам, сине сөймәсәм.* Зиннур Мансуров. *Бу турыда ул шундый шагыйранә, шундый тылсымлы итеп сөйләде, мин, матур хикәя тыңлаган кебек, тын алмыйча утырдым.* Г.Әпсәләмов

2) Шигъри рәвештә, шигъри осталык белән; шигъърияткә хас булганча; сәнгатьле итеп. *Бу җырда гаять шагыйранә рәвештә киная белән генә йөрәктәге хәсрәт ут белән тиңләштереләдер.* Гали Рәхим. --- *Гомәр Бәшировның халкыбыз гореф-гадәтләрен, матур йолаларын шагыйранә тасвирлаган «Туган ягым – яшел бишек» әсәре, Аяз Гыйләҗев, Әхсән Баян повестьлары Көнбатышта да кызыксынып укырлык, тик без аларны тәрҗемә генә иттерә алмыйбыз.* Т.Әйди

3) Матур, хозурлы булып; тантаналы, хисле итеп. --- *ак болытлар әллә ничек күңелне канатландыра, үзләре белән сине дә очыртып алып китәрләр сыман... Нугай даласы Галимҗанны әнә шулай шагыйранә каршылады.* Г.Мөхәммәдова

**2.** *с. мәгъ.* 1) Шигырьдә була торган, шигърияткә хас. *Әйе, буең да зифа, туба кеби, Шул мөкаддәс талга яфрактыр кулың. Шагыйранә сүз бу, аңларсың үзең, Бу сыйфатлардан ерагraктыр кулың.* Г.Тукай. *Бу сүзләрдә тамчы ялган да юк, Шагыйранә ялган димәгез...* Н.Сафина

2) Шигырьдә, шигъърияттә була торган кебек нәфис, матур, сәнгатьчә. *Коръәндәге илаһи бөеклекне шагыйранә бизәкләр белән матурлап, искиткеч җиңеллек, күтәренке рух, олы ышаныч белән сурәтләп биргән [Г.Тукай].* Д.Абдуллина

3) Шагыйрьләргә хас, шагыйрьләрчә нечкә хисле, романтик. *Бу – романның зәгыйфь, хатыннар табигатьле «Мәңгелек трагедия әһеле», үз юлында эшлекле, шагыйранә табигатьле, музыка тилесе бер Зыядыр.* Г.Ибраһимов. *Бертуктаусыз яктылык вә югарыга омтылган шагыйранә күңеленең кара көчкә бирелеп, аның тырнагында калмаганыны без аңлыймыз ---.* Г.Исхакый

4) *күч.* Матур, рәхәт, хозурлы. --- *Галия исемле Арча кызы барысыннан да өстен чыкты. Тавышы шагыйранә моңлы иде, лирик җырларны үзәк өзгеч аһәң белән башкара.* М.Әмирханов. *Моңарчы рәсемнәрдә генә күргән, ишетеп кенә белгән шагыйранә сихри дөньяның эченә барып керәсе килә.* К.Кәримов

**ШАГЫЙРӘ** *и. гар.* Хатын-кыз шагыйрь. *Ә Марина Цветаева ни дисәң дә шагыйрә. Оят, намус дигән нәрсә борчый башлагандыр аны.* А.Хәсәнов

**ШАГЫЙРЬ** *и. гар.* 1) Шигъри әсәрләр авторы, поэзия белән шөгыльләнүче язучы. --- *һәр шигырь язган кеше шагыйрь була алмаган шикелле, һәр диссертация яклаган кеше, минем уемча, галим түгел, чөнки гыйльми ачышларны диссертация якламый да эшләп була бит.* Н.Нәҗми. *Иген җыелып, табынга коймак булып килгәч кенә, игенче борчылудан туктый. Ә шагыйрь? Шагыйрь кулга китап кергәч тә тынычлана алмый әле. Укучылар ничек кабул итәрләр, китапның гомере озын булырмы?* Ф.Яруллин

2) *күч.* Хыялый, нечкә күңелле кеше, лирик. *Бәлки, шагыйрь күңелле җаннар чыннан да картаймый торганнардыр.* М.Вәлиев

**ШАГЫЙРЬЛӘ́РЧӘ** *рәв.* 1) Шагыйрьләр кебек, шагыйрьләр гадәте буенча. *Сөйләшүе дә гади генә, тәмәкене дә безнең авыл агайлары кебек беткәнче тарта, киеме дә шагыйрьләрчә түгел, югыйсә шигырьләрендә «якты еллар» да «бәхетле тормыш»...* И.Юзеев. *Чәчне шагыйрьләрчә озын итеп үстереп, артка тарап җибәргән. Тулы, түгәрәк йөзе сизелерлек сулыгып, агарып-нәфисләнеп калган.* В.Нуруллин

2) Шигъри, сәнгатьле, образлы итеп; чын сәнгать югарылыгында. *Ямаш Игәнәй поэзиянең зур миссиясе турында үзе дә күп язды. Шул бурычны чын шагыйрьләрчә үтәү өчен җиң сызганып эшләргә кирәк.* Ш.Галиев. *Чын шагыйрьләрчә, образлы итеп, тәэсирле итеп әйтелгән! Әйе, китапта менә шундый уңышлы мисаллар бик күп.* М.Вәли-Барҗылы

**ШАГЫЙРЬЛЕК** *и.* 1) Фикерне тезмә сөйләмдә образлы бирү сәнгате, шигырь язу эше, поэтик эшчәнлек. *Акмулланың шәхесе формалашуда һәм шагыйрьлек сәләте ачылуда башлап аның революциягә кадәр татар дөньясында танылган Эстәрлебаш һәм Троицкидагы «Рәсүлия» мәдрәсәләрендә укуы мөһим роль уйный.* Ф.Мусин. *Р.Әхмәтҗанов – үзендә шагыйрьлек куәсе булган өчен генә иҗат итә торган кеше түгел. Ул – ил тарихы, халык язмышы, аның бүгенгесе һәм киләчәге турында борчылып, әрнеп иҗат итүче шагыйрь.* Р.Фәйзуллин

2) Шигырь авторы, шагыйрь булу хәле, шагыйрь дәрәҗәсе. *Мондыйлары, күрәсең, шагыйрьлекне кәгазьгә*

*шома юллар тезеп, куплет саны буенча акча каеруда һәм дан алуда гына күрә.* М.Вәлиев. *Шигърияткә очраклы килеп эләккәннәре дә, тырышып-тырмашып шагыйрьлеккә дәгъва кылучылары да һәм, билгеле, сәләтлеләре дә җитәрлек.* Р.Миңнуллин

**ШАГЫЙРЬ-ШӨГАРА** *җый. и. гар.* 1) Шагыйрьләр. *Шагыйрь-шөгара халкы, ихтимал, бу гыйбарәне күңелендә шигарь итеп йөртәдер, чөнки Сүз аның өчен эш коралы да, яшәү максаты да, ризык-тәгаме дә ---.* Безнең мирас

2) *мыск.* Графоманнар, шагыйрь дип аталырга теләүчеләр, вак-төяк шагыйрьләр. *Ләкин үз язмышы турында түгеп аның уйлары. Мәдрәсәләр, ташпулатсарайлардан китүе, галим-голәмә, шагыйрь-шөгара мәҗлесләреннән аерылуы өчен пошынмый ул.* М.Госман

**ШАГЫРДАТУ** *ф. к.* **шыгырдату**. *Өр-яңа гимнастёрка-чалбар кигән командирлар, пилоткаларын кырын гына киеп, портупея каешларын шагырдатып, безнең контора тирәсендә иртәдән кара төнгәчә яңа оешкан подразделениеләренең йомышларын юллап йөри башладылар.* А.Расих

**ШАГЫРДА́У** *ф. к.* **шыгырдау**. *--- аның бу атаклы арбасы бөтен авылга ишетелерлек итеп шагырдый иде.* Ш.Маннур. *Кемдер келәне ычкындырып җибәрде, шагырдап эчке ишек ачылды, ут кабынды.* М.Хәбибуллин

**Шагырдап куюю** Кисәк, бер мәртәбә шагырдау

**Шагырдап тору** Гел шагырдау, шагырдый торган булу; хәзер шагырдау. *Шагырдап торган капка аша хан кадәр ханны кертеп булмый бит инде.* М.Хәбибуллин

**Шагырдый башлау** Шагырдарга тотыну

**ШАГЫРТ** *иярт. к.* **шыгырт**

**ШАГЫ́РТ-ШОГЫРТ** *иярт. к.* **шыгырт-шагырт.** *Чәмчәле читекләр киеп, шагырт-шогырт басып йөргәнен күргәч, башта мин аны берәр бай кызыдыр дип йөргән идем.* М.Гали

**ШАГЫ́Р-ШАГЫР** *иярт. к.* **шыгыр-шыгыр**. *Ахырда, күңелендәге шайтан коткысына буйсынып, шагыр-шагыр бәкегә таба китте.* Э.Касыймов

**ШАГЫ́Р-ШОГЫР** *иярт.* Бертуктаусыз чыгып торган, төрле югарылыктагы шыгырдау тавышларын һәм шыгырдау рәвешен белдерә. *Кар һәм йолдызлар яктысы гына төшкән урамнан шагыр-шогыр атлап кызу гына барабыз.* Ә.Еники. *Әнә яр астында ике баганасы гына тырпаеп калган. Шул баганалар өстендә зур су тәгәрмәче иде. Ул шагыр-шогыр әйләнә.* М.Яһудин

**ШАГЫР-ШОГЫ́Р ИТҮ** *ф. к.* Төрлечә шагырдау; бик нык шагырдау

**ШАГЫР-ШОГЫ́Р КИЛҮ** *ф. к.* **шагыр-шогыр итү**. *Ишекләр рәтләп ябылмый. Шагыр-шогыр килә. Шуларның шыгырдавына бала уянып, елый башлый.* Ф.Яруллин. *Анда кеше сыярлык кечкенә бүлемтекләргә, ягъни кабиналарга кереп утырасың да кораб мачтасы кебек шагыр-шогыр килә башлаган буыннарыңны, умыртка сөякләреңне кыздырасың.* А.Хәлим

**ШАДРА** *и. фар.* **1.** 1) Тәндә чәчәк авыруыннан калган вак-вак чокырчык рәвешендәге эзләр. *Аның шактый ук куе булып шадра сибелгән озынча алсу бите чыннан да пешеп җиткән кура җиләккә охшаган иде.* Г.Бәширов. *Елмайган вакытта, шадралары тары ярмасы сыярлык кына булып кечерәяләр икән.* М.Мәһдиев

2) Битендә вак-вак чокырчыклар рәвешендәге чәчәк авыруының эзләре булган кеше. *Миңнулла шуннан алып кайткан күчтәнәчләр белән чәй эчеп купканнар гына иде, әлеге шул шадра килеп керде.* В.Нуруллин. *Шадра минем борын төбендә ниндидер кәгазь кисәген болгап алды.* М.Әмирханов

3) *күч.* Берәр өслектәге уенты, чокыр, тигезсезлек, кытыршылык. *Көл өстендә нәни шадралар гына уелып кала.* Г.Сабитов. *Инде җирнең кыштан калган чокыр-чакырлы шадраларын тигез үлән каплады…* К.Кәримов

4) *күч.* Су өстендәге вак дулкынчыклар, тигезсез, тәңкә-тәңкә, чуар булып күренгән җир. *Диңгез шадраларын нурга манчып, Кояш чыкты балкып, зураеп.* М.Җәлил

5) Тап, тимгел. *Астрофизиклар Кояш йөзендәге ямьсез шадраларның юкка чыгуын дөньяга хәбәр итәргә ашыктылар.* А.Тимергалин

**2.** с. *мәгъ.* 1) Чәчәк авыруыннан калган вак-вак чокырчыклары булган; шундый йөзле. *Читекче Таҗи дигәннән, исемә төште әле, аларның бер шадра кызлары бар иде.* Г.Камал. – *Ай-яй, тәмле ис тараткансыз, – диде ул, шадра танавының киң тишекләрен киереп иснәп.* А.Гыйләҗев

2) Өслеге рельефлы, керенте-чыгынтылары булган, тигезсез. *Иге-чиге күренмәгән зәңгәр күл өсте, андагы эреле-ваклы меңләгән дулкыннарда чагылган кояш күл өстен тоташ шадра көзгегә әйләндергән.* Д.Каюмова. *--- шомлы гүләү тавышы ишетелде. Сәүбән шадра диварга колагын куеп тыңлый башлады.* Г.Гыйльманов

3) Тукылышы вафляга охшаган, чокырланып торган шакмаклар барлыкка китереп сугылган; гомумән кытыршы (тукымалар тур.). *Наилә шадра сөлге белән Нәҗипнең тирләгән муенын сөртте, беләзегеннән тотып тамыр тибешен санады, ничә икәнен әйтмәде.* А.Гыйләҗев. *Халык телендә «тастымаллык» дип аталган шадра тукымадан, кулдан, эре атлатып тегелгән һәм әле беренче тапкыр гына киелгән ак күлмәк, кызыл киҗеле кыска киндер ыштан ---.* А.Хәлим

4) Төсе тоташ булмаган, тимгелләре булган, ала-кола, чуар. *Шадра түшәм аны сытарга теләгәндәй тагын да аскарак иңгән, су төбе сыман тонык яктылык белән тулган бүлмә суынган ---.* А.Гыйләҗев. *Күктән җиргә иңгән шадра болыт көчен күтәрә алмаган озын керфекләр күзне каплаганнар, җылы болытны үзенә сеңдергән акыл ялга туктаган.* Т.Галиуллин

5) Вак кына дулкыннар белән капланган. *Алда мольберт – шадра су өслеге ---.* Э.Гадел. *Шул ук вакытта болыт төрле ихтыярларны тәненә сеңдергән җылы, шадра диңгез чалымнарын да үзенә җыеп алган.* Т.Галиуллин

◊ **Шадра кәгазь** *к.* **наждак кәгазе**. *Фикердәше академик Миркасыйм Госманов бер язмасында Аязның «шадра кәгазь кебегрәк (наждак кәгазе) кытыршы холкы, пычак шикелле үткен теле» дип үз итеп әйткән сыйфатларын нәшрият тормышында шәхсән миңа күрергә туры килмәде.* Р.Батулла

**ШАДРАЛАНДЫРУ** *ф. к.* **шадралату**. *Салкын җил исә, күрәсең, сука суыгы җиткәндер, төньяк җиле вокзал лабазы артында җыелып торган мазутлы суларны шадраландыра, сабакташым Мансур белән минем ач үзәкне өзеп, муеннан кереп балактан чыга торган шәфкатьсез җил исә.* М.Мәһдиев

**Шадраландырып тору** Гел, даими шадраландыру, хәзер яки вакытлыча шадраландыру

**Шадраландырып узу** Юл уңаеннан, үтешли шадраландыру. *Җил торган саен океанны дәһшәтлерәк селкетә, зур-зур дулкыннарны шадраландырып уза иде.* А.Толстой

**ШАДРАЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **шадралау**. *Эре тамчылардан шадраланган юлдан үргә менеп килгәндә, машинадагы ике кеше кинәт ялтыраган яшен яктысыннан күзләрен чытырдатып йомып, коточкыч шартлаудан муеннарын җыердылар.* М.Маликова

2) Шадра **1.** (*1 мәгъ.*) чыгу, шадралар белән каплану. *Чәчәк авыруыннан бит шадралану*

3) Бәрелү, таушалу, кителү, кырылу һ.б.ш. нәтиҗәсендә тигезсез хәлгә килү, тигезсезләнү. *Якындагы ак өйләрнең кабыргалары мылтык ядрәләре белән шадраланган, җиргә түшәлгән ташлар кызыл кан белән юылган имеш, дип сөйлиләр.* Г.Ибраһимов. *Юлда төрле ташларга бәрелеп аның бераз гына йөзе шадраланса да, элеккеге матурлыгын, элекке кызыллыгын җуймаган [алма].* Ф.Яруллин

4) Дулкынлану, шома өслектә сырлар барлыкка килү. --- *ә күл өсте сизелерсизелмәс кенә шадралана, тимгелтимгел тибрәнеп тора иде.* Г.Әпсәләмов. *Диңгез өсте шадраланган, диңгезчеләр мондый һаваны «свежо» дип йөртәләр.* М.Мәһдиев

5) Шадра **2.** (*1 мәгъ.*) рәвеш алу, шундый өслекне хәтерләтү. *Түбәләрдән тамчы тама, кар басыла, өсте бик юка гына шадраланыпката...* Ә.Еники

**Шадралана төшү** Аз гына шадралану. *Салпы ияге бераз шадралана төшкән...* Р.Мөхәммәдиев

**Шадраланып алу** Аз гына вакытка шадралану. *Кинәт кенә исеп куйган җилгә су өсте шадраланып ала да тына һәм бу күренеш тагын, тагын кабатлана.* Г.Галиев

**Шадраланып бетү** Нык шадралану. *Стеналары ядрәләр тиюдән шадраланып беткән ике катлы кызыл кирпеч бинаны казарма иткәннәр.* Ф.Хуҗин. *Зифа сынлы каен түгел инде – әйләнгән ул күптән кырыска. Шадраланып беткән. Кәүсәсе дә әверелгән каты корычка.* Р.Миңнуллин

**Шадраланып калу** Берәр нәрсә нәтиҗәсендә шадраланган хәл алу. *Яфракларында, кәүсәләрендә яңгыр тамчылары җемелдәшкән каеннар, тупыллар, бармак калынлыгы тузаны басылып, шадраланып калган юл – кичәге яңгырның телсез шаһитлары – тирә-юньгә сафлык бөркәләр сыман.* Ә.Гаффар. *Йөзе шадраланып калмас бит?* Ю.Гыйльванова

**Шадраланып китү** Тора-бара шадралану; бераз гына шадралану. *Бервакыт Хәятның зиһенендәге Салих чынлап та шадраланып китте.* Ф.Әмирхан. *Әз генә җил исеп, су өсте шадраланып киткәндә, шәүлә киртләч-киртләч булып сына, әллә ничә җирдән өзелә.* Г.Гобәй

**Шадраланып кую** Кинәт шадралану. *Разия искә төшү белән, бәгъремнең йөзе шадраланып куйды.* А.Хәлим

**Шадраланып тору** Шадра булып күренү. *Вакыты белән чабулап, шадраланып торган болганчык су эченә шуып төшә [машина]. Аннары яңадан җанфәрманга моторын үкертеп, юл өстенә күтәрелә.* М.Хәсәнов. *Минем читекнең балтырлары шадраланып торачак.* Н.Кәримова

**Шадраланып чыгу** Тиз арада нык шадралану. *Иреннәре кысылып куйды. Ияге шадраланып чыкты. «Нервылар кысылган» дип уйлап алдым.* В.Нуриев

**ШАДРАЛАТУ** *ф.* 1) Шадра **2.** (*1 мәгъ.*) итү, шадра хәлгә китерү. *Чәчәк авыруы кайчандыр аның бераз битен бозган, шадралаткан иде.* М.Әүэзов. *Уң кашының бер чите, йөзен шадралаткан чәчәк авыруы чагында, бераз чокырланып калган.* Г.Ибраһимов

2) Шома өслекне тишкәләү, телгәләү, чокыр, уенты барлыкка китерү. *Кичәге җылы яңгырдан соң беләү ташы кебек шомарып калган юеш сукмакны яңгыр суалчаннары тишеп шадралаткан.* Г.Сабитов

3) Дулкыннар барлыкка китерү, дулкынландырып, чуарлау. *Шул тавышны алып киткән җил көзгедәй күлнең өстен урман ягына таба йөгергән нәни дулкыннар белән шадралата.* А.Алиш. *Нинди хозур: диңгез итәген Шадралатса җилләр, назласа! Хисең түгел, хәтта битләрең Диңгез белән охшаш лабаса.* М.Хөсәен

**Шадралата төшү** Бераз, җиңелчә шадралату; тагын да ныграк шадралату

**Шадралатып җибәрү** Бераз, җиңелчә шадралату

**Шадралатып кую** Сирәк кенә, кисәк, азга гына, җиңелчә шадралату. *Тик ара-тирә балыклар сикергәләп кенә ул көзге өстен бераз шадралатып куйгалыйлар.* В.Нуруллин

**Шадралатып тору** Гел, даими шадралату, хәзерге моментта шадралату. *Киң елганың буеннан-буена йөгерек җил исеп, су өсләрен шадралатып тора.* Г.Әпсәләмов

**Шадралатып узу** Юл уңаеннан, үтешли шадралату. --- *ачы җиле белән юлында очраган һәр кешенең битенә китереп бәрә, дала буйлап чәчелеп яткан күлдәвек йөзләрен шадралатып уза, үләннәрнең башын җиргә бәрәбәрә кыйный.* Р.Вәлиев

**ШАДРАЛА́У** *ф.* 1) Шадралар (*1 мәгъ.*) барлыкка китерү, шадралату

2) Шадралар (*2 мәгъ.*) барлыкка китерү; тигезсезләү. *Таң атты, тузаннан күбенгән юлларны ялгыз яңгыр тамчылары шадралады ---.* М.Мәһдиев. *Ул битен җилләр шадралаган борынгы балбал шикелле.* Н.Нәҗми

**Шадралап бетерү** Нык шадралау

**Шадралап җибәрү** Бераз шадралау

**Шадралап йөрү** Шадралау белән мәшгуль булу. *Җил шадралап йөри сулар өстен, Нинди кызык таба торгандыр?* Н.Арсланов

**Шадралап кую** Сирәк кенә, кинәт, бер мәртәбә шадралау. *Елга тыныч. Тик әллә нигә бер генә бала җил су өстен җыерып, шадралап куя.* И.Гази

**Шадралый башлау** Шадраларга тотыну

**ШАДРАЛЫ** *с.* 1) Шадрасы (*1 мәгъ.*) булган. *Зарифның сирәк-мирәк кенә булып чәчелгән шадралы тут йөзендә хозурланудан туган җиңелчә генә елмаю чагылды.* М.Хәсәнов. *Чигәдән агара башлаган чәче, зур зәңгәр күзләре, вак шадралы йөзе, кечкенә җыйнак авызы, сөйләшкәндә матур ялтырап китә торган алтын теше, укучыларга карата сабыр мөгамәләсе – барысы гел элеккечә, безне укыткандагы кебек.* Р.Хәбибуллина

2) Кытыршы, тигезсез. *Карт каршыдагы бөрчек-бөрчек шадралы панель йортка төртеп күрсәтте...* А.Вергазов

3) Бөрчекле, таплы. *Чаларган мыеклы, базык гәүдәле карт, соры шадралы пиджәк чабуын җилдә җилфердәтәҗилфердәтә, ух та вах килеп капка төбендәге каты бозны чыртлатып чабып маташты ---.* А.Вергазов

**ШАДРАЛЫК** *и.* Шадра булу үзенчәлеге. *Җитмәсә бүтәннәрдән үзенең шадралыгы белән дә аерылып торган бу кеше сүзнең җаен белеп кенә, тәмле итеп кенә сөйләшергә ярата.* С.Рәфыйков. *Шадралыгы йөзен бозса да, бу ир чибәр, күркәм кеше.* А.Гыйләҗев. *Уртача шадралык өстенә карасу көрән йөз аны африкалыларга охшата.* М.Харисов

**ШАДЫРВАН** *и. фар.* Башлыча мәчетләр ишегалдында булган, тирәсендәге краннардан һәм уртасындагы фонтаннан су ага торган, өсте гөмбәзле яки ачык бассейн. *Йөздән артыграк мәчет*

*арасында Хисар (1597), Шадырван (1636) исемлеләре борынгылыклары белән атаклы.* Т.Әйди

**ШАЕ** *бәйл. диал.* 1) Берәр нәрсә зурлыгында, күләме белән шуның кебек, шуның кадәр. *Соң, безгә шул шае эшләп мондый гына булмә тиешме?* К.Тимбикова. *Былтыр көзнең беренче айларында «Ватан» дигән газетабыз соңгы битен тутырып, ат башы шае хәрефләр белән бер белдерү бастырып чыгарды.* Р.Гариф

2) Билгеле вакытка чаклы, шуңа кадәр. *Бу утын кара көзгә шае җитә, кышка да керә, мал-туардан калган камыш, бәрәңге сабаклары, курпы, кизәк белән кушып якканда шөкер итәрлек бәрәкәтле була.* Ә.Гаффар

**ШАЖГЫРТУ** *ф.* Кискен хәрәкәт белән һаваны сызгырту, чыжлату, чаж-чож иткән тавыш чыгару. *[Гофрай Миркәйгә:] таягы белән шажгыртып суга.* Н.Исәнбәт

**ШАЖГЫРУ** *ф. сөйл.* Чажылдау, чыжлау, чажгыру, чаж-чож иткән тавыш чыгу

**Шажгырып тору** Шажгыру үзлеге булу

**ШАЙГЪ БУЛУ** *ф. иск.* Таралу, таралыш алу; һәркемгә барып җитү. *Кайчан ки ошбу кара хәбәр Мәккәдә шаигъ булды.* К.Насыйри. *Китапның мәале халкымыз арасында бик шаигъ булган үги балаларга илтифат итмәү мәсьәләсе мөляхәзә кылынганга, табигый, бу китапта үги балаларның хәлләре бик начарлыгын мөхәррир әфәнде бик ачык тасвирлар берлә күрсәтергә тиеш иде.* Г.Исхакый

**ШАЙГЪ ИТҮ** *ф. иск.* Тарату, һәркемгә җиткерү, билгеле итү. *Вә васыять итте ки, мин үлгәч, минем үлгәнемне шаигъ итмә.* К.Насыйри. *Ул моны беркемгә дә шаигъ итми иде.* Ф.Әмирхан

**ШАИГЪ КЫЛУ** *ф. иск. к.* **шаигъ итү**. *Вә ул таҗиргә фәһемләтте ки, бу йөк фәлән әмирнең хатыныннан фәлән әмирнең хатынына һәдиядер, дип шаигъ кылдылар.* К.Насыйри

**ШАЙ** I *с. диал.* **1.** Бәрабәр, тиң, тигез, бердәй. *Ел белән ел шай түгел, яз белән көз җәй түгел.* Мәкаль

**2.** *бәйл. мәгъ.* Чагыштыру мөнәсәбәтен белдерә; кебек, шикелле. *Ул да сугышның беренче елыннан кайтты, минем шай.* М.Хуҗин. *Әйе-әйе, алар сүзне таба инде. Безнең шай аптырап тормый.* Р.Рахман

**ШАЙ** II *кис.* **1.** Раслау, шикләнү, чикләү һ.б.ш. мәгънәләр өстәп яки көчәйтеп килә торган кисәкчә. *Сәгать ярым чүбек чәйнәп, бер рәтле фикер дә әйтмичә, Хәмзә Хәерчи трибунадан төшеп китте. Котылдык шай, дип кул чаптык.* Г.Афзал. *Азынды ул, адәм сөягеннән Кузна уйнап, казна бөлдереп... Төрле битлек киеп кыланды шай, Хамелеоннан да уздырып.* Л.Шагыйрьҗан

**2.** *ы. мәгъ.* Шомлану, шөбһәләнү, гаҗәпләнү һ.б.ш. мәгънә төсмерләрен белдерә. *– Җәсти Патыйма үпкәләмәс, шай, – диде. Н.Гыйматдинова. Томан артыннан чыкты ай, кызармады йөзе, шай!* А.Азимов

**ША́Й** III *и. иск.* Әсбап, деталь, бизәк

**ША́ЙБА** *и. нем.* 1) *тех.* Винт башы яки гайка астына кидереп калдырыла торган яссы бөҗра рәвешендәге деталь; алка. *Пычкы кучәренә калынрак шайба кидереп, бушаган шөребен ныгытып кына куясы югыйсә.* Ф.Абдуллин

2) *спорт.* Хоккей уйнау өчен зур булмаган авыр резин диск. *Дуслар, капкага кергән һәр шайба саен түшәмне күтәрерлек итеп кычкыра-кычкыра, хоккей карадылар.* Ф.Яруллин

◊ **Шайба куу** Хоккей уйнау. *Һәм үзе бер малайның кулыннан таягын суырып алып шайба куарга кереште ---.* Г.Әпсәләмов. **Шайба куучы** Хоккейчы. *Милләтне футболчылар да, шайба куучылар да күтәрә алмый.* Д.Гыйсметдин. **Шайба сугу** *к.* **шайба куу**. *Ишегалдында бер көтү малай шайба суга иде.* Г.Әпсәләмов. *Мәсәлән, Алсу Рәхимова, егетләрдән уздырып, шайба суга.* Т.Нәҗмиев

**ША́ЙБАЛЫ** *с.* 1) *тех.* Шайбасы булган; алкалы. *Шайбалы болт*

2) *спорт.* Шайба белән уйнала торган. *Әйтик, башкалада шайбалы хоккей бәйгесен үткәрердәй боз сарайлары бармы?* Кызыл таң. *28–29 июльдә «Олимп» боз сараенда шайбалы хоккей буенча «Җәйге хезмәттәшлек кубогы»на Бөтенроссия турнирын ачу уеннары булды.* Хезмәт даны

**ША́ЙКА** *и. төрек* 1) Берәр явыз ният белән тыелган гамәл, җинаять эшләү өчен тупланган төркем; өер; банда. *Тизрәк Карый волкомына кайтырга да, шуннан кораллы отряд алып килеп, айнып җиткәләгәнче, Шакир-бандитны да, аның шайкасын да кулга алырга!* В.Нуруллин. *Йортны күрсәтүче, шайканы анда озатып куючы Ания үзе булды.* Р.Габделхакова

2) *сөйл.* Күңел ачып, комачаулап, эшсез һ.б.ш. рәвешле йөргән яки артык күп кешедән торган компания, дуслар төркеме (мыскыллап, өнәп бетермичә әйтелә). *«Үзең пычрак ташыган гына җитмәгән, шайкаңны ияртеп кайткансың», – диячәк.* Ф.Яруллин

3) *куч.* Өер. *Шундый бер җинаятьчел, кешеләргә бик үчле этләр шайкасының башлыгы Полкан кушаматлы бер дигән немец овчаркасы.* А.Хәсәнов. *Соңрак бер хакыйкатькә төшенде Бибисара: бүреләр-кавемдәшләр чит төркемдәге ырудашын тиз генә үз шайкасына сыйдырмый икән.* Н.Гыйматдинова

**ША́ЙКАДАШ** *и.* Кем беләндер билгеле бер шайкада булган кеше, шайка тәшкил иткән кешеләрнең берсе. *Бандит үзенең эзләрен бик оста яшерә. Инде берничә дистәгә җиткән шайкадашлары булыша аңа.* М.Әмир. *Ләкин хөкем итәргә өлгерә алмый калдылар. Иректә калган шайкадашлары коткарган тегеләрне.* В.Нуруллин

**ШАЙМАН** *и. иск.* Кирәк-ярак, дирбия. *Тимгел чуар атым бар, Шул атыма мением, Шайман таккан сыным бар, Шайман тагып килием; Киерелмәле җәямне Киереп-тартып күрием ---.* Дастан. *Бу турыда елга киңәйгән шикелле, аның каравы суның тирәнлеге атның корсагына да җитми. Хәтта олаулардагы шайманнар белән ризыклар да суга тимәячәк.* В.Имамов

**ШАЙТАН** *и. гар.* **1.** 1) *дини* Фәрештәләрнең җитәкчесе була торып Аллаһыга каршы баш күтәргәне өчен, Аллаһ тарафыннан куылган барлык; Иблис. *Шайтан – Адәм белән Хәуваны җәннәттән чыгарган явыз зат*

2) Шул барлыкның дәвамы буларак адәм балаларында булган, аларны котыртып, туры юлдан яздырып, аздырып торган явыз көч. *Кыскасы, шул: шайтан күңелне ничек кенә итеп вәсвәсәләндереп тормасын, Шәйхигә тел тидерергә ярамый иде әле...* В.Нуруллин

3) *куч.* Кеше күңеленең тискәре ягы, нәфес, усаллык һ.б.ш. шундый сыйфатлар җыелмасы. *Тик күңеленә кереп оялаган шайтан аны гел кирегә котырта иде.* Х.Ибраһим. *Көнчелек, хөсетлек дигән шайтан һаман да үз тырнагыннан ычкындырмый.* М.Макаров. *Юк, нәфес дигән шайтан җилкәгә менеп атланган да чыбыркылый да чыбыркылый.* Ә.Галиева

4) *куч.* Явыз ниятле, әшәке, усал кеше. – *Мин аны [яралыны] караңгы*

*төшкәч, барып алмакчы да булган идем, менә бу шайтан җибәрмәде, – диде ул һәм бармагы белән снайперга төртеп күрсәтте.* А.Шамов. *Мусинның соңгы араларда Костя Балабанов белән этлемәчеле яшәвен искә алсаң, Дардиевның кайсы шайтанга хезмәт иткәнен чамалау тагын да кыенлаша...* З.Фәтхетдинов

5) *куч.* Берәр кешене ачуланып, сүгеп, тиргәп эндәшү яки атау сүзе. *Сукыр шайтан, дим, тавык мие эчкән карт пәри, дим, беренче бәрелүең түгел бит, карабрак йөрергә булмыймыни?..* М.Әмир. *Нишләп юлга чыкты икән соң ул, шайтан малай?* В.Нуриев

6) *куч.* Зарарлы, начар тәэсир итә торган, кирәкмәгән, файдасыз һ.б.ш. нәрсә. *Әле генә эчкәнен үзе дә сизми калган аракы дигән шайтан кызның эчен яндыра, миен томалый.* Н.Әхмәдиев

**2.** *ы. мәгъ.* Үкенү, шөбһәләнү, гаҗәпләнү, соклану, канәгатьсезлек һ.б.ш. мәгънә төсмерләрен белдерә. *Гата сәхнә артыннан аккордеонда ниндидер бер марш уйнап җибәрде. Оста, шайтан!* М.Мәһдиев. *Шайтан, болар белән бәйләнсәм, соңга калам инде.* Р.Кәрами. *Һидият Дәүләтханов, Нигъмәтҗан Зарипов, тагы, тагы әллә кемнәр кул куйган, шайтан!* Р.Камал

◊ **Шайтан алгыры** Җиңелчә үкенү, сукрану, соклану һ.б.ш.ны белдерә торган сүз. *Бер кашык су белән йотарлык гүзәл, шайтан алгыры!* Н.Әхмәдиев. *Их, шайтан алгыры, әллә инде шул хатынга акча гына бирәсе дә котыласы калган?* И.Сираҗи. **Шайтан арбасы** Автомобиль, трактор һ.б.ш.ны өнәмичә атау сүзе. *Тракторны кул чабып каршы алдылар Картлар гына нигәдер шомлана төштеләр. Җирне ат белән сөреп тә тамак туйдыра ала идек әле. Нигә китергәннәрдер бу шайтан арбасын?* М.Юныс. *Заманында мондый техниканы «шайтан арбасы» дип атаганнар.* М.Кәбиров. **Шайтан ачыткысы** *к.* **шайтан суы**. *Чир китәр, гадәт китмәс. Шайтан ачыткысы элгәрләр сүзенә дә үзенчә төзәтмә кертергә өлгерде. Икенче төрле әйткәндә, эчкечелек китмәс чиргә, китмәс гадәткә әверелде.* Зиннур Мансуров. **Шайтан аягын сындырырлык** 1) Җыйнаксыз, пычрак, тәртипсез. *Аннары баз өстенә күчтеләр. Монда да тупланган әйберләрдән шайтан аягын сындырырлык.* М.Хәсәнов. --- *зонадагы тимерьюл буйлары төрле чүп-чар белән тулган, йөргәндә шайтан аягын сындырырлык.* Г.Тавлин; 2) Буталчык, аңлашылмый торган; хаталы. *Ә инде күптомлыкларның искәрмәләр өлешенә тирәнрәк үтеп керсәң, анда хәтта шайтан аягын сындырырлык урыннар да бар.* Мәдәни җомга. **Шайтан бармагы** Күптәннән үлеп беткән башаяклы моллюсклар гәүдәсенең таш булып каткан очлы цилиндр формасындагы арткы өлеше, белемнит ташы. *Чын мөселман кирәкярагы: теш чистарта торган мисвәк агачлары, гатырша майлары, дарчин, канәфер, бадьян, сагыз, сарытамыр, күкташ, шайтан бармагы шикелле дару һәм им-том әйберләре.* Ә.Фәйзи. **Шайтан белә** *к.* **шайтан белсен**. *Ленин бабай төзегән җәмгыятьтә халыкны талап җыелган миллионны бүлешү бара. Беләсеңме шуны? Кем малыдыр, анысын шайтан белә.* Т.Миңнуллин. *Башкага мин өйләнә алмыймын. Өйләнер идем, куркам. Кем булып чыгар минем хатын? Шайтан белә!* Р.Батулла. **Шайтан белгән** *к.* **шайтан белсен**. *– Бу тамганың да безне кая китереп чыгарасын шайтан белгән, – диде Шәүкәт, һаман да бирешмичә.* А.Хәсәнов. *Шайтан белгән, анысы нинди төркемдер инде аның.* Ә.Сафиуллин. **Шайтан белсен** Мин белмим, билгесез. *Шайтан белсен, бәлки, чыннан да, китапка гашыйктыр, библиофилдыр?* А.Тимергалин. *Шайтан белсен аны, мин бу якларга хатынга ияреп, Себердән кайткан идем ---.* Н.Гариф. **Шайтан да** Һичбер кем яки һичбер нәрсә, бөтенләй беркем яки бернәрсә дә (булмау, күренмәү һ.б. тур.). *Монда шайтан да ярдәм итмәс.* Х.Камалов. *Әйе, мондый кыяфәттә аңа ир-ат түгел, шайтан да якын килмәячәк!* Х.Ширмән. **Шайтан да булмау** Бернинди дә зарар күрмәү, берни булмау, һич зарар тимәү. *Шайтан да булмас, алыгыз шул өстерәлчекне!* Т.Гыйззәт. *Баш сау булса, аякка шайтан да булмый, ди иде.* Г.Әпсәләмов. **Шайтан зәмзәме** *к.* **шайтан суы**. **Шайтан коткару** Исерткеч эчемлек эчү. --- *ирен сүгә хатын, кот алып: «Бишбалтада әтәч кычкырганчы, инде кайттың... шайтан коткарып!»* З.Мансуров. **Шайтан каргаган** Бик начар, кыен, тискәре, уңай, әйбәт ягы булмаган (урын, эш һ.б.ш. тур.). *Электән бу яклар халык телендә: «Шайтан каргаган, карга да очмый торган як», – дип йөртелгән.* Х.Садри. **Шайтан мөһере** Берәр кешене гөнаһлы, кара көчләр белән бәйле дип санап, аның тәнендә шайтан калдырган эз дип күзалланган миң, тап кебек нәрсә. *Нинди шайтан мөһере булсын ди, безнең нәсел тамгасы ул!* Г.Гыйльманов. **Шайтан сабагы** *иск.* Дини белемнән аермалы буларак, файдасыз, дингә зыян гына китерә дип исәпләнгән дөньяви белемнәр, мәктәпләр, гомумән яңача белем бирү системасы. *Акча санарга шайтан сабагы нигә хаҗәт?* Г.Әпсәләмов. *Өйрән, укы син шайтан сабагын, әллә нинди китапларны, гөнаһысы үзеңә булыр!* Р.Батулла. **Шайтан сидеге** *к.* **шайтан суы**. *Ир башына шул шайтан сидеге җитә!* А.Гыйләҗев. **Шайтан сөте** *к.* **шайтан суы**. *Яңа гына йотып куйган шайтан сөте һәм шушы уй шагыйрьгә кыюлык өстәп җибәрде...* И.Сираҗи. **Шайтан суы** Аракы; гомумән исерткеч эчемлек. *Ильяс улым, сүземне авырга алма, сине бераз теге шайтан суы белән шаяргалый, диләр.* Н.Акмал. *Шайтан суына якын да килә торган кеше түгел иде Хәлил, нахак гаеп белән кабергә төшерделәр газизен.* А.Әхмәтгалиева. **Шайтан такмагы** Дога, мөнәҗәт кебек дини эчтәлекле текстлардан аермалы буларак дөньяви җыр, такмак һ.б.ш. нәрсәләр. --- *җарый, кузыкаем, утыз җыр булгандыр кый. Бөгенгә җитеп торыр бу шайтан такмагына. Санап карасам, исем-акылым китте: егерме тугыз да, утыз бер дә түгел, төгәл утыз җыр язганмын икән.* Н.Әхмәдиев. **Шайтан таңы** Таң атмас борын күк йөзендә сыек яктылык барлыкка килү, нурлар уйнап алу; ялган таң. *Телебездә әлеге «ялганчы таң» сүзенә тәңгәл «шайтан таңы» дигән төшенчә бар.* А.Тимергалин. *Офыкта ниндидер яктылык уйнап алды кебек. «Тагын бер шайтан таңы» – дип ачынып уйлап куйды Әхмәтсафа.* Ф.Сафин. **Шайтан тартмасы** Зыянлы, кирәкмәгән һ.б.ш. нәрсә буларак телевизор. --- *йокымнан уянып китеп, шайтан тартмасын ачып җибәрсәм, малай, ни күрим, шул прокурор чынлап торып эшсез калган!* Ф.Баттал. *Балалар барында телевизор кабызып булмый хәзер, тәмам шайтан тартмасына әверелде...* З.Мәхмүди. **Шайтан тәгәрмәче** 1) Вертикаль урнаштырылган, тиз әйләнә торган тәгәрмәч рәвешендәге күңел ачу аттракционы; 2) Кайта-кайта борчып торган, хәл ителеп бетми торган кыен мәсьәлә, озакка сузылган мәшәкать. *Бәла бит бу! Котылу мөмкин булмаган хәл. «Шайтан*

*тәгәрмәче» барлыкка килә. Нишләргә?* Х.Камалов. *Янган чырай белән фотога төшеп, яңа паспорт алу бәхетенә ирештем. Пенсия җайлаганда, тагын китте шайтан тәгәрмәче. Кайда янган, ни өчен янган, кем яндырган, кем аны күреп торган? Бу тормышта ниләр бар?* **Шайтан тәпие** *к.* **шайтан алгыры**. *Ай, шайтан тәпие, вакланган шакмак та беткән ләбаса.* Н.Гыйматдинова. **Шайтан төкергән** 1) *к.* **шайтан каргаган**. *Шайтан төкергән җир – менә ул нәрсә селина!* Н.Фәттах; 2) *к.* **шайтан алгыры**. *Симай кесәләрен капшана башлады, ләкин эзләгән нәрсәсен тиз генә таба алмады. – Әй, шайтан төкергән, мин аны ыштан балагына ук төшергәнмен икән!* Ш.Маннур. **Шайтан төкереге** к. **шайтан суы**. *Менә хәзер иптәшебез шайтан төкереге алып кайта.* М.Фәйзи. *Алар чиратлашып шешәдәге шайтан төкереген йотып куйдылар.* Ф.Яруллин. **Шайтан туе** 1) Өермә. *Шайтан туе гөрли җил белән...* Б.Ибраһим; 2) Ыгы-зыгы, шаушу, мәшәкать; шау-шулы, ыгы-зыгылы җир. *Игезәк бәбәйләре дә булса, өй эчләре музыка мәктәбенә, шайтан туена әйләнә икән.* А.Гыйләҗев. *Менә бу газаплы минутлар да үтә. Кирәкле кәгазьләрне алуга, кузгалып та китәбез. Уф, бу шайтан туеннан котылдык бит.* Җ.Рәхимов. **Шайтан урлау** Әле генә булган, күргән әйберне таба алмау, югалту. **Шайтан фигыле** Гомуми кабул ителгән нормаларга туры килми торган кыланыш, гөнаһ, оят булып саналган эш-гамәл. *Әйе, әдәби иҗатта да ашыгу – шайтан фигыле, ягъни иң явыз дошман.* А.Тимергалин. **Шайтан чакыру** Кирәкмәгән, килешмәгән хәрәкәтләр ясау, сүз сөйләү һ.б.ш. *Шайтан чакырып, таягыңны селкеп йөрмә монда!* Г.Камал. **Шайтан ширбәте** *к.* **шайтан суы**. *Ә шайтан ширбәтен бераз авыз иттеңме, акыл һәм зирәклек дигәннең исеме үк онытыла, балаларга һәм хатынга бирелгән вәгъдәләр бөтенесе бергә җилгә оча.* Ә.Баян. **Шайтаным да** Бөтенләй, гел, аз гына да, һич, асла. *– Армиядә кем идең син? – Сапёр. – Сапёр! – диде Солтан, үкенеп. – Ә фортификацияне шайтаным да белмисең.* Ә.Гаффар

**ШАЙТАНБАЛЫК** *и. зоол.* Кармакчыбалыксыманнар отрядыннан ашарга яраклы диңгез балыгы; диңгез шайтаны; *русчасы:* **морской чёрт**

**ШАЙТАНИ** *с. гар.* 1) Шайтанга хас, шайтаннан килә торган, шайтандагы кебек. *Ә инде шайтани хисләргә бирелеп, куркып калсак һәм, Тәңребез ярдәменә ышанмыйча, иманыбыз ныклыгын какшатсак, йөзтүбән тәгәрәвебез дә ихтимал.* Рашат Сафин. --- *ниндидер кызыксыну көче, әллә кайдан калкып чыккан яшерен шайтани тойгы әдәплелек төшенчәсеннән өстенрәк булып чыкты.* Г.Галиев

2) Мәкерле, явыз, усал. *Уйланган саен, Иосиф Сталинның коточкыч сак һәм хәйләкәр булуына таң каласың. Ул – чыннан да гигант. Шайтани хәйлә һәм мәкер гиганты.* А.Тимергалин

3) Мыскыллы, кимсетүле

4) Шомлы, куркыныч. *Ишаннарга һичбер вакыт шайтани төш иңми.* К.Тинчурин

**ШАЙТА́Н КҮБЕГЕ** *и. бот.* Төче суларда тереклек итә торган болыт; *русчасы:* **бадяга**. *Татар телендә мифик образларга, халык ышануларына нигезләнеп ясалган үсемлек атамалары шактый. Бу семантик төркемгә: --- шайтан күбеге ‘бодяга’, ‘плакун трава’, аждаһа агачы ‘драконово дерево’, пәйгамбәр тырнагы ‘календула лекарственная’, пәри кычытканы ‘яснотка’, пәри акбашы ‘тысячелетник’, Сөләйман мөһере ‘Соломонова печать’ (купена лекарственная), фәрештә куагы ‘донник’ һ.б. керәләр.* Г.Саберова

**ШАЙТАНЛАНУ** *ф.* 1) Коткы, ялган, хәйлә кебек тискәре эшләр белән шөгыльләнү; явызлану, мәкерләнү. *Такталы авылына барабыз, анда интеллигентлар күп, шуларның эченә кереп чыгарга кирәк. Шайтанланып, халыкны котыртып яталар.* Ә.Моталлапов

2) Һәртөрле мәзәк нәрсәләр белән мәшгуль булу, кылану, шаяру, шуклану, мәш килү. *Яшьлеккә хас юләрлекләр белән Шайтанланган чаклар күп булган. Ярамастай эзләр тапталган да Вакыт белән ярый онытылган.* В.Галиев

**Шайтанланып алу** Берара, бераз гына шайтанлану

**Шайтанланып йөрү** Теләсә кайда, теләсә ничек шайтанлану. *Сеңлем Сәвия белән мин әтиләр тирәсендә шайтанланып йөрибез.* Ватаным Татарстан

**ШАЙТАНЛЫК** *и.* 1) Кешенең күңелендәге нәфес, көнләшү һ.б.ш. тискәре сыйфатлар; шайтан вәсвәсәсе. *Сине күргәч, шайтанлыкны оныттым, әйтерсең лә бәхет кошын мин тоттым, өметсез – шайтан, дигәннәр дөрес ул, ә син менә өметлегә юлыктың.* Н.Кәримова

2) Кешене котырту, аздыру, коткы салу, ялгыш юлга этәрү кебек гамәлләр; әшәкелек, этлек. *Падишаһ, Сәяхәтченең тарихын ишеткәч, Алтынчыны арада шайтанлык кылып йөргән өчен астырырга боерды.* Кәлилә вә Димнә. *Хатын әйтте: – И падишаһ, углан гөруһының бәгъзыларында шайтанлык вә бәдбәхетлек күп булыр.* К.Насыйри

3) Явызлык, кансызлык, кешелексезлек; шундый гамәлләр. *Автобусларга кереп шартлатулар, балалар йортына, мәктәпләргә кереп һөҗүм итүләр – шаһидлек түгел, ә шайтанлык.* А.Гыйльми

**ШАЙТА́Н ТАЯГЫ** *и. бот.* Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан юан сабаклы, чәнечкеле каты яфраклы, кызгылт шәмәхә чәчәкле күпьеллык үсемлек; убыр таягы, чәнечкеле шайтан таягы; *русчасы:* **чертополох**. *Ул арада йомран оя-өне янындагы шайтан таягына уткойрык кунды, бу кошчык та кемнедер үз кырына дәшә, койрыгын селкә-селкә сайрый башлады.* М.Хәбибуллин. *Читтән караганда күзнең явын алып, балкып торган бу гөл, якынрак килгәч, шайтан таягы булып чыккан.* М.Маликова

◊ **Шайтан таягы кебек** 1) Бик сәламәт, нык, теләсә нинди авыруга һ.б.ш.га чыдам; 2) Артык чая, бик әрсез; 3) Ямьсез, кыяфәтсез. *Нишләп соң әле ул чәчкә кебек менә дигән хатын-кыз шайтан таягы кебек Маликка кияүгә чыккан?!* Д.Гыйсметдин

**ШАЙТА́Н ТЫРНАГЫ** *и.* 1) Бармакларда тырнак төбе тирәсендә тиренең теленеп, кайтарылып торган бер нечкә, кечкенә кисәге. *«Кичен тырнак кисәргә ярамый, шайтан тырнагы чыга!» – диләр иде.* Ш.Галиев

2) *к.* **шайтан таягы**. --- *язучы тормышның таҗгөлләрен, нәркис, шалфейларын гына түгел, шайтан тырнакларын, әрем, кычыткан, алабуталарын да күрергә, белергә тиеш.* С.Поварисов

3) *к.* **шайтан бармагы**. *Кирмәннән яз-җәй айларында капчык асып чыгып китә дә, утыз-кырык көн югалып торгач, урман-болыннардан җыйган чәчәкүләннәрен, шайтан тырнаклары, елан тиреләре, болан мөгезләре, куян тизәкләре белән тутырылган биштәрләрен көчкә күтәреп, арып-талып, ябыгып бетеп кайтып керә икән.* Р.Сәгъди

**ШАК** *иярт.* 1) Агач, таш, сөяк кебек каты әйбер берәр каты өслеккә төшкәндә, бәрелгәндә барлыкка килә торган кыска, өзек тавышны белдерә.

*Көне буе балта яңгыратып, шак та шок утын яра.* Ш.Галиев

2) Каты әйбер белән кисәк сугу, бәрү рәвешен белдерә; шап. *Биш-алты адым гына атлаган иде, Гәрәй абзыйның маңгаена кемдер шак итеп китереп тә бәрде.* А.Фәләх. *Әлбәттә, бөтенесе тәртиптә иде һәм Алик, әкрен генә сүгенеп, ишеген шак итеп ябып, баскычтан түбән төшеп йөгерде.* В.Исламетдин

**ШАКАЙ** I *рәв. диал. к.* **акай**. *Искәрмәстән генә Һадиның каршысына барып басып, күзләрен шакай итү иде ниятем.* М.Хәсәнов

**ШАКАЙ** II *и. диал.* Тубык сөяге. *Күреп үткәнчә, шаталак-шакалак сөяге шул ук ашыкны яисә тубык сөяген белдерә. Әлеге «атаклы» сөякне Минзәлә ягында шакай сөяге дип тә әйтәләр икән.* Н.Фәттах

**ШАКАЙТУ** I *ф. диал. к.* **акайту**. *Мин дә ятам күз шакайтып.* Яңарыш

**ШАКАЙТУ** II *ф. диал. к.* **шакырайту**

**ШАКАЛ** *и.* 1) Этләр семьялыгыннан башлыча чүл, дала һәм урман-дала зоналарында тереклек иткән, вак хайваннар, кош һәм бөҗәкләр, шулай ук үләксә белән туена торган ерткыч хайван; чүл бүресе, чакал. *Шакал бераз туктап торды да тагын якынрак килеп улый башлады.* Г.Әпсәләмов. *Вакыт-вакыт каравылда торучы солдатның иптәшенә сүз катуы, кайдадыр далада ач шакаллар тавышы ишетелеп китә.* С.Рәдиф

2) *күч.* Намуссыз, ертлач кеше. *Аның максаты долларлар суырып алу булган. Шул кәсеп белән тамак туйдыручы шакал икәнен сиземләве кыен идемени?* Т.Галиуллин. *Үзем булганда сиңа бер генә шакал да кул күтәрмәячәк, гарантия бирәм.* Р.Сәгъди

**ШАКАРУ** *ф. диал.* 1) Бер якка нык каерып тоту, тарттырып кую. *Дистәләгән куллар шакарып алып, мөгаллимне баганага боргычлап бәйләде.* А.Хәлим. *Кара-кара: берсе атының авызлыгыннан ук шакарып тотып алды түгелме?* Д.Бүләков

2) Атның башын хәрәкәтләнмәслек итеп, бер якка каерып яки өскә табан каратып бәйләп кую, беркетү. *Ул шаркылдап көлгәндәй итте һәм, яхшы ат кебек, авызын һавага шакарды, чишелмәгән бүрек колакчыннары арасында бүре тешедәй эре черегән тешләре саргаеп яктырды...* А.Хәлим. *Кара айгырны станокка алып кереп, башын югары күтәртеп, шакарып бәйләп куйдылар.* З.Зәйнуллин

**Шакарып кую** Шакарып, шул хәлдә калдыру. *Үзе сөйләнгән арада ике куллап атны баганага шакарып куйган тезгенне чиште.* З.Зәйнуллин

**ШАКАЮ** I *ф. диал.* 1) *к.* **шакыраю**. *Әмма җилләү урынына бишмәт итәге минуттан минутка шакаеп ката барды.* Ф.Хөсни. *Үктәбер ахырлары, җир шакаеп туңган, әмма кар яумаган, шуңа күрә арба белән йөрергә туры киләдерие.* В.Нуруллин

2) Бернинди хәрәкәтсез катып басып, утырып тору яки гәүдәне катырып, иелми-бөгелми йөрү. *Яшел үлән арасында калкып торган кызыл балчык өеме алдында шигырь сөйләп утырып булмый ич! Бер сүзсез шакаеп утыру да күңелне өркетә иде.* Ф.Хөсни. *Озын чәчле, ыспай гәүдәле, хәрбиләрчә шакаеп – гәүдәсен төп-төз тотып йөрергә ярата.* Ф.Сафин

**ШАКАЮ** II *ф. диал. к.* **акаю**. *Тик иртәгәсен газетаны кулына алгач, күзләре шакайды.* М.Әмирханов

**ША́К ИТҮ** *ф.* Шак кебек тавыш чыгару. *Монда таштан башка нәрсә булыр икән? Әнә көрәк ташка шак итеп төртелде.* А.Гадел

**ША́ККАТАРЛЫК** *с.* **1.** 1) Искиткеч шәп, таң калдырырлык, хәйран итә, сокландыра торган. *Читтән игътибар иткән кешегә монда әллә ни шаккатарлык нәрсә дә юк кебек.* Ж.Дәрзаман. *Палитра бай, буяу кунасы шаккатарлык. Ә җиде төс бергә кушылганда, Ходай яраткан җиһанның ак төсен – яктылыгын тоеп, гаҗәпкә каласың!* Р.Камалетдинова

2) Гадәти булмаган, сәер, көтелмәгән, гаҗәп, гаҗәпкә калдырырлык. *Алда әйтеп үткәнемчә, әсәрдә шаккатарлык бернәрсә дә юк кебек.* В.Нуруллин. *Каз беренче күкәен салды, карыйм, зур да түгел, кечкенә дә түгел. Шаккатарлык бернәрсәсе дә юк ---.* Н.Кәримова

**2.** *рәв. мәгъ.* Бик, нык, искиткеч, соң дәрәҗәдә. *Шаккатарлык матур, төз иде бу сын, шул ук вакытта өнсез калдырырлык шомлы иде.* М.Маликова. *Язучылар арасында гомер буе: – Гөлсем бит ул – искиткеч чибәр ханым! – дип сөйләделәр. --- Ә инде Ринат абый белән бергә укырга килгәндә, ул тагын да шаккатарлык чибәр булгандыр.* Ю.Сафиуллин

**3.** *хәб. мәгъ.* Гаҗәп, сәер, хәйран. *Менә моңа чынлап та шаккатарлык иде.* М.Хәбибуллин. *Уйласаң шаккатарлык инде, өеңә авып торырдай урман булсын да утынга тилмер инде.* Н.Кәримова

**ША́ККАТКЫЧ** *с. к.* **шаккатарлык**. *Ул бөтенләй шаккаткыч түгел, мин, миллионерларның бөтен җире алтын-көмештәндер, дип уйлаган идем.* И.Юзеев. *Һәм шунда тагын бер шаккаткыч хәл булды. Көчкә өчкә укыган Айнур һәрбер фәннән бишлегә укый башлады.* Ф.Габделхакова

**ША́ККАТМАЛЫ** *с. к.* **шаккатарлык**. *Ә хәзер моңсу, кайгылы, булган җырларны да бии-бии такмаклап җырлыйлар, шаккатмалы.* Д.Ханнанова. *Башкалар инде галәм кораблары, шаккатмалы акылга ия булган компьютерлар ясыйлар.* Г.Нурулла

**ША́ККАТУ** *ф.* 1) Нык гаҗәпләнү, сәерсенү. *Гади бер колхозчы баласы өчле-дүртле билгеләренә генә укыса, хәтта икеләләр алгаласа да, моңа бер дә алай шаккатып карамыйлар.* В.Нуруллин. *Изил Латыйпов! Үзе! Шул! Күзенә дә, колакларына да ышанмады Нәҗип, шаккатты.* А.Гыйләҗев

2) Бик нык соклану, таң калу, хәйран калу, кызыгу, мөкиббән китү. *Парашютлар бик шәп безнең, күрсәгез шаккатыр идегез.* Р.Вәлиев. *Алар агач күләгәсеннән кошларның зәңгәр күктә очып йөрүләренә кызыгып карап торганнар, бөҗәкләрнең кояшта кызынып ятуларына һәр елдагыча шаккатканнар.* А.Имамиева

3) Берәр эш-хәлнең, сүзнең кинәтлегеннән, гаҗәпләнүдән һ.б.ш.дан аптырап калу, нишләргә дә белмәү. *Кулларын болгый-болгый малайларга якынлашкан Хәлиулла абый, шаккатып, урынында катып калды. Нидер әйтергә дип ачылган авызыннан сүзе чыкмады.* Р.Галиуллин

**Шаккатып калу** Нәрсәгәдер кинәт шаккату. *– Фазлыев, су алып кил! – Бу боерыкка Шилов та, Мурзыев та шаккатып калдылар. Блиндаждан чыгу белән немец снайперлары аны теге дөньяга озатачак.* Х.Камалов

**Шаккатып тору** Хәзер, сөйләү моментында шаккату; күпмедер вакыт шаккаткан хәлдә булу. *Өстәлендәге бер кочак ак розаларны күреп шаккатып торды.* М.Әхмәтшина

**ША́ККАТЫРГЫЧ** *с. к.* **шаккатарлык**. *Аның язмаларында кайвакыт шаккатыргыч яңалыклар да булмаска мөмкин.* Ф.Яруллин. *Чатырның эче*

*үзенә бер шаккатыргыч могҗиза иде.* М.Әмирханов

**ША́ККАТЫРУ** *ф.* 1) Таң калдыру, хәйран калдыру; сокландыру, кызыктыру. *Галәмне айкап төшкән космонавтларга да артык исе китми башлаган безнең заман халкын фән кандидаты булу белән генә шаккатырып булмый да булмый инде.* В.Нуруллин. *Ни күрсен, алан тулы яшь кызлар бииләр, җырлыйлар. Кызларның матурлыклары аучыны шаккатыра.* З.Хөснияр

2) Нык гаҗәпләндерү, гаҗәпкә калдыру. *Яшьләрдә тотрыклылык азрак, тамыр җибәреп өлгермәгән – алар модага тизрәк иярүчән, никадәр читтәнрәк, ятрак, сәеррәк булса, шулкадәр ныграк ябышалар. Шаккатырасы, үзенә каратасы килә бит.* Ш.Галиев. *Шундый вакыт килеп җитә, безне бер генә нәрсә, бер генә күренеш-вакыйга да шаккатыра алмас кебек тоела башлый.* И.Нәбиуллина

3) Аптырашта калдыру, тетрәндерү. *Ләкин Миңнулланы барыннан да бигрәк шаккатырганы Михайлов өстендәге ак офицер киеме булды. «Әллә акларга сатылган микән бу!?» – дип тетрәнеп куйды Миңнулла.* В.Нуруллин. *«Немецлар тарафыннан атып үтерелгән кеше мин», – диде карт, шулчак мине шаккатырып.* М.Яһудин

**Шаккатыра килү** Электән үк, күптәннән, эзлекле рәвештә шаккатыру. *Заман модернистларын көнләштерерлек җиңел дә, гади дә, даһи да ясалган бу рәсемнәр гасырлар буена сәнгать белгечләрен шаккатыра килгән.* Р.Батулла. *Мәскәү, Петербург, Уфа гына түгел, хәтта инде Казан галимнәренең дә татар тарихын бүгенге Татарстан – шул ук Мәскәү тарафыннан, Ленин һәм Сталин тарафыннан кискәләнгән һәм өч-дүрт мәртәбәгә киметелгән Татарстан белән генә киртләп куюы безне һәрчак шаккатырып килде.* В.Имамов

**Шаккатыра тору** Әледән-әле шаккатыру

**Шаккатырып йөрү** Шактый озак, һәрвакыт, һәркайда шаккатыру. *Андый эшләрдә күп нәрсәне белештермәгән Мөхәммәтҗан бабасы, минем онык укырга кергәндә дә беренчелекне бирмәгән, иң яхшы сөйләүче булган имтиханда, --- дип, бик озак кеше шаккатырып йөрде.* Р.Рахман

**Шаккатырып кую** Көтмәгәндә шаккатыру. *Кышларын да, коеп, яңгыр ява, Соңгы карны юа торганы. Көтмәгәндә шаккатырып куя Июньдәге карлы бураны.* Н.Әхмәдиев

**Шаккатырып тору** Даими рәвештә, еш яки әледән-әле шаккатыру. *Ул Фатыйма карчыкны әледән-әле шаккатырып торды.* М.Кәбиров

**ША́ККАТЫРЫРЛЫК** *с.* **1.** Шаккатыра, хәйран калдыра торган, таң калдырырлык дәрәҗәдәге. *Бу авылдан китәм, китәм, диебрәк йөрдем. Шаккатырырлык идарә йортын әллә кайчан балкытып куя идем... Сызымнарын Казанда эшләттем.* А.Гыйләҗев. *Ул яшьтән үк зурга омтылды, бөтен кешене шаккатырырлык картиналар иҗат итәргә, шөһрәт казанырга теләде.* М.Маликова

**2.** *рәв. мәгъ.* Шаккатырып; хәйран калдырырлык итеп, таң калдырырлык дәрәҗәдә. *Моның өчен Аллаһы Тәгалә үзе шаһит, бөтен авыл халкын шаккатырырлык итеп әзерләнде.* С.Поварисов

**ШАКМАК** *и.* **1.** 1) Алты тигезьянлы турыпочмаклыктан торган геометрик җисем; куб. *Сигез кырлы шакмак өстендә кысыла төшкән гөмбәз сыман түбә калкып тора.* Н.Фәттах. *Чамалыйсыздыр инде, бу башваткыч алты ягы алты төскә буялган шакмак рәвешендә ясалган, үзе кечерәк 26 шакмактан тезелгән.* Й.Миңнуллина

2) Тигезьяклы турыпочмаклык рәвешендәге геометрик фигура; квадрат. *Менә ул, себеркесен бер читкә ыргытып, Атлас янына килеп утырды һәм кып-кызыл тырнаклы бармаклары белән сызымдагы шакмакларга күрсәтә-күрсәтә сөйләп тә китте ---.* Г.Рәхим. *Бу рәсемнәрдә кояшның үзе түгел, хәтта нәни нуры, шәүләсе дә юк, алардан соң Малевичның атаклы кара шакмагына карап та күңел ял итәрлек иде.* Р.Габделхакова

3) Куб формасындагы балалар уенчыгы. *Мин кечкенә вакытта Рубик шакмагы үзен хөрмәт иткән һәр кешедә булгандыр кебек. Соңыннан бу уен онытылып торды, һәм менә хәзер мин бу төсле шакмакларны яңадан очрата башладым.* Й.Миңнуллина. *Энесе Гариф искергән кызыл ашъяулык өстендә шакмаклар тезеп утыра.* Р.Рахман

4) Гомумән куб формасындагы, шуңа охшаш берәр деталь, корал, әсбап һ.б.ш. кирәк-ярак. *Әнвәр утын ярырга да бик оста иде, җиргә тезләнеп утырды да кыска түмәрләрне җәһәт ваклап атты. Шул шакмакларны капчыкка тутырдылар һәм кухняга китерделәр.* Х.Камалов. *Тирә-якта агач өйләр генә түгел, хәтта кызыл балчыктан сугылган, эре-эре яндырылган шакмаклардан салынганнары да бар иде.* И.Хуҗин

5) Квадрат, турыпочмаклык формасындагы берәр нәрсә. *Комиссиядә өчесе дә өлкән яшьтәге кешеләр, берсе кителенә өч рәт орден шакмаклары таккан, сыңар куллы иде.* М.Мәһдиев. *Баюга борылган кояш эре күксел шакмаклардан укмаштырып торгызылган тугызар катлы йортларны, киң, озын юлларны нурга коендырган иде.* М.Маликова

6) Кисәк. *Карчык кунакларны капка төбендә озатып калды, балаларның башыннан сыйпады, икесенә дә берәр шакмак шикәр тоттырды.* А.Гыйләҗев. *Старшина сугышчыларга шырпы тартмасыннан да кечерәк берәр шакмак сабын биреп чыкты.* Х.Камалов. *Айгөл, шытырдата-шытырдата кәгазеннән сүтеп, шоколад сындырып капты, икенче урыныннан бер шакмак сындырып, Иреккә сузды.* Ф.Садриев

7) Домино, шашка һ.б. уеннарда кулланылган, уенына карата төрле төсле, формалы, тамгалы булган махсус пластиналарның берсе. *[Домино уйнаучыларның өченчесе:] Алай итеп уйнагач, уен буламыни инде ул, китер монда шакмакларыңны! (Шакмакларны тартып ала.).* Г.Камал. *Ярар, артык кыстап эчен пошырмыйк дигәндәй, хан якыннары кайсы шатранҗ уйнарга тотынды, кайсы нәрд шакмакларын таратты.* Р.Батулла

8) *к.* **шакылдавык**. *Җаннөшеткеч хәбәрне сугыш елларында төн сакчысы булып шакмак кагып йөргән аксак Сәлим алып килгән ---.* Н.Хәсәнов

9) Берәр өслектә төс яки сызык белән аерылган дүртпочмак, квадрат. --- *әти фанердан ясап биргән, сары-кызыл, яшел-зәңгәр шакмакларга буялган үземнән зур сумкамны алга-артка селеккәләп аламын.* К.Миңлебаев. *Тышы кызылга буяп, ялтыравык җиз тасмалар белән шакмак ясап уратылган.* М.Маликова

10) Таблица, график, бланк, сызым кебекләрдә тутыру, берәр билге кую, язу һ.б.ш. өчен буш калдырылган аерым бер урын; күз. *Буш шакмакларга хәрефләр тезелделәр. Иң читеннәре ахырга кала барды. Сәлманов өчен кроссворд чишүнең иң ахыргы минутлары кыйммәт.* М.Мәһдиев. *Аннары конвертка, бөтен шартын китереп, шакмаклар эченә сызып, индекс саннарын, адрес язды да хатны төшке ашка*

*барганда почта әрҗәсенә салырга дип кесәсенә тыкты.* Г.Рәхим

**2.** *с. мәгъ. к.* 1) **шакмаклы 1.** (3–7 мәгъ.). *Казан шәһәренең игезәкләрдәй бер калыптан суккан шакмак йортлар тезелгән яңа микрорайонында, гөнаһ шомлыгына каршы, күптән онытылган бер үләт базыннан «әл-хәлир әл-вабаи» хастасы тарала ---.* А.Тимергалин. *Мин аның янәшәсенә килеп утырдым, һәм без хәзер икәүләп чәй эчәбез. Шакмак шикәр һәм җәймә белән, үз телебездә шаян сүзләр әйтешеп.* Т.Кәримов

2) *күч.* Артык гади, тупас, нәфислек җитмәгән. --- *Мидхәткә чәче кыска итеп алынган йомры башлы, шакмак иякле, сәер карашлы адәм чекерәеп карап тора иде.* М.Маликова. *Михаил өреп тормады, нәфрәте, ярсуы шулкадәр көчле иде, авызына җыйналган кан катыш төкереген беренче секретарьны «куркыныч җинаятьчедән» саклап калу шатлыгыннан тантана иткән тук милиционерның шакмак чыраена төкерде.* Ә.Гаффар

◊ **Шакмак борын** Ямьсез, тупас кыяфәтле. *Ленинградта эшләгән чакта, Җамалиише шакмак борыннарны чакрым ярым ташлый торган иде.* А.Алиш. **Шакмак кадәрле** Бик зур. *Синең, Гайшәнең һәм минем фамилияләр шакмак кадәрле хәрефләр белән басылырлар.* Г.Кутуй. **Шакмак күз** Әрсез, бәйләнчек. *[Җилбикә:] Нәрсә, шакмак күзләреңнән үзең үк курыктыңмы?* Ф.Яруллин. --- *Нәрмин, ул шакмак күз бүтән бәйләнмәдеме? Тагын бәйләнсә, безгә әйт.* Г.Каюмов. **Шакмак күзле** Әрсез, бәйләнчек кеше турында. *Син дә теге шакмак күзле егетне телгә ала күрмә.* Г.Каюмов. **Шакмак сугу** Домино, шакмаклы яки башка шундый уен уйнау. *Биредә иң күңелле һәм иң шау-шулы урын – доминочылар өстәле. Дөрт кеше дөньяларын онытып шакмак суга, унлапунбишләбе карап тора.* Г.Әпсәләмов

**ШАКМАКЛАНДЫРУ** *ф.* 1) Гаҗәпләнү, курку, кинәтлек һ.б.ш.дан зур итеп ачу, акайту (күз тур.). *Эрна үзсүзле кызларга гына хас түземсезлек белән, күзләрен шакмакландырып, миңа текәлде.* М.Әмирханов. *Барысы да, күзләрен шакмакландырып, алар ягына борылып карады.* А.Вергазов

2) Ямьсез итеп ачу, җәйрәтү (авыз тур.). *Әнисенең аяк тавышы басылып җитмәстән, «елый белми торган» бала, авызын шакмакландырып, разбой салырга тотынды.* Ф.Яруллин

**Шакмакландырып тору** Хәзер шакмакландыру. *Нәрсә күзләреңне шакмакландырып торасың?*

**ШАКМАКЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **шакмаклау.** Бер як ярда йөзү бассейны. *Ул җиңелчә басмалар белән әллә ничәгә шакмакланган.* Х.Хәйруллин. *Мәктәп дәфтәреннән ертылып алынган шакмакланган кәгазьне Абзый кулына алды.* Л.-Х.Таналин

2) Шакмак формасына керү, шакмак формасын алу; шакмаклар хасил итү; шакмак булып күренү. *Әмма бер-ике адым да атларга өлгермәде, факультет бинасының шакмакланып күтәрелгән юан колонналары артыннан сискәндереп каршына көтмәгәндә ул килеп чыкты.* Ф.Латыйфи. *Ташу калдырган ләм шакмакланып ярыла, кояш кыздырудан гына түгел инде бу, үләннәр баш төртүе дә сиздерә.* М.Хуҗин

3) Гаҗәпләнү, курку, кинәтлек һ.б.ш.дан зур итеп ачылу, акаю (күз тур.). *Рәния башта, төшендәге тәэсирләрдән арына алмыйча, шакмакланган күзләрен әнисенең борчулы йөзенә текәп торды ---.* А.Вергазов. *Беләсезме, сез ачулана күрмәгез. Шулай да сезнең иртән, күзләрегез шакмакланмаган чагыгыз әйбәтрәк.* Г.Каюмов

**Шакмаклана бару** Торган саен ныграк шакмаклану. *Таш йортлар күләгәсендә җаны да «шакмаклана барган» кешеләр арасында әдипнең тыны кысыла башлый.* М.Галиев. *Иремнең болай да зур түгәрәк күзләре аның саен зурая, шакмаклана баруын күреп, аны тынычландырырга ашыгам ---.* Идел

**Шакмакланып бетү** Нык шакмаклану. *Яшел ызаннар белән шакмакланып беткән кыр өстендә, дулкын-дулкын булып, зәңгәр рәшә йөзә.* А.Алиш

**Шакмакланып килү** Әкренләп шакмаклану. *Күзләре күләгәдә, эре, ак тыгыз тешләре, шакмакланып килгән ияге генә күренә.* М.Маликова

**Шакмакланып китү** Күзгә күренеп, сизелерлек шакмаклану. *Гәүдә бермәбер җәелгән, авырайган, шәт, бер йөзйөз ун килограмм чамасы булыр; хәтта ки башы да әүвәлгедән зурайган шикелле, түрә кешеләр башы сыман, ничектер шакмакланып киткән.* Р.Солнцев

**Шакмакланып тору** Шакмакка охшау, шакмак формасында булу. *Янәшәсендә шундый егет калкан булып торсын әле. Кара костюмнан, ыспай гәүдә, тимер кебек тыгыз мускуллы иңнәре шакмакланып тора.* М.Галиев. *Алар ничектер, төрмә тәрәзәсе сыман, күңелгә шом салып, аркылы-торкылы шакмакланып торалар иде.* Ф.Абдуллин

**Шакмакланып чыгу** Нык шакмаклану. *Көтелмәгән хәбәрдән мулла малаеның күзләре шакмакланып чыкты.* Н.Әхмәдиев

**ШАКМАКЛАП** *рәв.* 1) Аерым шакмакларга бүлеп. *Башта табага май салып, шакмаклап туралган гөмбәне кыздырасы, борыч, тоз өстисе.* Р.Юнысова. *Миңнур бу сорауга алты дистәдән артык вакыт узгач та җавап бирә алмый. Торфны шакмаклап кисләргә бүләләр дә әйләндерә-әйләндерә киптерәләр, ә көзен ул кисләрне әрдәнәләргә өяләр.* З.Мәхмүди

2) Шакмак рәвешендә ясап, шакмак формасына китереп; шакмак хасил итеп. *Ул кечкенә көрәге белән шакмаклап карны ачкан, алдына ике тишек тишкән, икесенә ике кармак салган.* Ф.Садриев

3) Почмаклап, почмаклар ясап. *Ул текәлеп ректорның шакмаклап ясалган кара кысалы күзлегенә карады, әмма калын пыяла күз алмаларын зурайтып күрсәткәнгә, алар һәрвакыттагыча гаҗәпләнгән кебек тоелалар, асылда, бу кешенең ни уйлаганын белеп булмый иде.* М.Маликова. *Ул зәңгәр күзле, сары бөдрә чәчле зур гына курчак чыгарып утыртты, аның астына шакмаклап бөкләнгән ниндидер чүпрәк кыстырды.* Ф.Садриев

4) Шакмак исәбе белән, берәр шакмак итеп. *Аналары бик саран бит аларның, тәкә суюы түгел, шикәрне дә шакмаклап кына бирә.* Т.Гыйззәт

5) Шахмат тәртибендә. *Шомартылган таш аралаш шакмаклап җизбакыр җәелгән юлларның ике ягына тезелгән эре сөякле, таза, тук сакчылар тавыш-тынсыз озатып калдылар.* Н.Фәттах

6) *күч.* Артык гади, тупас итеп, нечкәләп тормыйча. *Аларда гуманизм икән ичмаса! Үз союзларына язмаган һәм язмаячак картларны да, мәкалә яки шакмаклап такмак сырлаштырган кешеләрне дә, хәтта тәрҗемәчеләрне дә кабул итеп кенә торалар икән.* Ф.Баттал

**ШАКМАКЛАУ** *ф.* 1) Шакмакларга бүлү; шакмаклар ясау; шакмак-шакмак итеп ясау. *Кызыл һәм саргылт төскә шакмаклап сугылган ашъяулык тирәли чәй эчәргә утыргач та, Айбиби юк-юк та Гаязетдин ягына карап алгалады.* М.Хәбибуллин. *Фирдәүсә китап киштәләре уртасында шакмаклап калдырылган урындагы калын-калын папка-*

*ларга, кечкенә язу машинкасына бармаклары белән кагылып-кагылып алды.* Ф.Садриев

2) Берәр өслектә туры почмаклар барлыкка китереп бер аркылы, бер буйга сызу, берәр нәрсә кую, беркетү һ.б. --- *Баязид ашарга бирелә торган чиикмәкләрдән шахмат фигуралары ясаган, ялгызы уйнар өчен кесә кулъяулыгын күмер белән сызгалап шакмаклаган иде.* Г.Ибраһимов. *Фанердан киселгән тактасын шакмакладык, кызылга һәм карага буядык та рәхәтләнеп уйный башладык.* Р.Нуруллина

**ШАКМАКЛЫ** *с.* **1.** 1) Шакмагы (*1 мәгъ.*) булган, кубиклар беркетелгән. *– Аягына шакмаклы нәрсә кигән, баулар белән бәйләп куйган, – ди.* Ш.Галиев. *Элекке заманнарда бу төбәктә агач кайрысыннан ясалган «шакмаклы» чабаталар (күтәртмәле) һәм төпле башмаклар кигәннәр.* Милли-мәдәни мирасыбыз: Нижгар татарлары

2) Шакмагы (*2 мәгъ.*) булган, квадратлар беркетелгән. *Мичкә сайгак буенча салмак кына тәгәрәп барды да елтыр шакмаклы сандыкка бәрелеп туктады.* Г.Сабитов

3) Шакмак (*1 мәгъ.*) формасындагы, куб рәвешендәге. *Хәниф карт, сәфәренең көткәннән дә уңышлырак булуына куанып, сарык ите саткан акчасына кибеттән биш кило ак он, ярты кило зур шакмаклы шикәр һәм бер такта кытай чәе алды.* Н.Әхмәдиев. *Әле шушы арада бер журналда күрдем, шәһәр уртасына махсус берничә авыл өен күчереп салганнар. Шакмаклы, җансыз йортларга шул өйләр ямь биреп тора.* Р.Вәлиев

4) Шакмак (2 *мәгъ.*) формасындагы, квадрат рәвешендәге. *Әрҗәнең шакмаклы ояларында башлары сургычлы шешәләр ялтырап утыра иде.* Н.Фәттах. *Аның тышлыгында шлем кигән, шакмаклы мыеклы чибәр Ворошилов елмаеп тора, ә еракта үрмәли-бүкәли ак финнар кача.* М.Мәһдиев

5) Гомумән турыпочмаклы, кырлы. *Һәм тышына алтын белән Мәскәү Кремле ясалган шакмаклы шешәнең пыяла бөкесен ачып, бармакларын чылатты да колак артларына, муенына сөрткәләде...* М.Маликова. *Борылгысыз булып әйбер тутырылган ванна бүлмәсенең бер почмагында тартмага охшаган шакмаклы нәрсә тора ---.* Ф.Садриев

6) Кисәкле. *Төенчек эченнән тагын ике кисәк иллешәр граммлы 189 бөртек чәй, ярты кило чамасы эре шакмаклы шикәр, укмашып беткән карамель һәм шулай ук ярты кило чамасы печенье чыкты.* Н.Фәттах

7) Аерым шакмакларга (*8 мәгъ.*) бүленгән, шакмаклардан торган, шакмаклап эшләнгән. *Нинди карарга килергә, ни эшләргә белмәде, кызыл шакмаклы ашъяулык белән кысып бәйләнгән төенчеген бер кулыннан икенчесенә күчергәләде.* М.Хуҗин. *Ишегалдында аны-моны каранып йөргән Бәһиҗә түтәй Бикташның күз алдында уңайсыз итеп янтаеп иелде дә шакмаклы дәфтәр битенә төрелгән төргәкне табып алды.* М.Маликова

8) *күч.* Артык гади, тупас, нәфислек җитмәгән. *«Сикертмәле озынча борыны белән шакмаклы олы иягенә хәтле нәкъ эти инде», – дип уйлады ул.* З.Хәким. *Шакмаклы йөз, алга чыгып торган ияkләр, күзләр кара...* Р.Зәйдулла

**2.** *и. мәгъ.* 1) Җиргә шакмаклар (*8 мәгъ.*) сызып, шулар аркылы агач кисәге һ.б.ш.ны тибеп йөртеп, сикереп уйнала торган балалар уены; сызык уены. *Ачлыкны онытып тору өчен, лидлар төрле уеннар уйлап табалар. Шул рәвешчә, шакмаклы уйнау, ашык, туп уеннары һәм (шахмат уеныннан кала) башка төр уеннар уйлап табыла ди тарихчы.* Н.Фәттах. *Берәүләре китап укый. Икенчеләре шакмаклы уйный.* Р.Батулла

2) Шашка, нәрд кебек уеннарның гомуми атамасы. *Хуҗа тагын күзлекле белән шакмаклы уйнарга утырды.* Р.Батулла

**ШАКМАКЧЫК** *и.* Күмәк уйнала торган кайбер өстәл уеннарында, комарлы уеннарда тәгәрәтеп җибәреп йөреш чиратын, отыш күләмен яки җиңүчене билгеләү өчен хезмәт иткән, һәр ягында билгеләре булган кечкенә кубик. *Альпинистлар, шакмакчыкны чиратлап ташлап, фишкалар ярдәмендә йөреш ясыйлар.* Г.Сиражева

**ШАКМА́К-ШАКМАК** *рәв.* **1.** Шакмаклап, шакмакларга бүлеп, шакмакка охшатып. *Вәзыйх, ак таштан шакмак-шакмак кисеп салынган йортларны күреп, уйларын бүтән нәрсәләргә күчерде.* Х.Камалов. *Әй шушы агач телне! Шакмак-шакмак турап мичкә ягасы!* Н.Гыйматдинова

**2.** *с. мәгъ.* Шакмаклы, шакмак формасындагы. *Безнең яктагыларга һич охшамаган, юка, кызыл балчык кисәкчәләре белән ябылган текә түбәле таш өйләр, шакмак-шакмак кына кырлар, таш юллар, юл буендагы кыркылган җимеш агачлары, урманнары үтәкүренмәле, – бездә боларны урман дип тә атамаслар иде.* Г.Әпсәләмов. *Карасу зәңгәр күк стенасы белән җир кушылган турыда бик кечкенә булып Иртыш буе урманнары күренде, тасма булып аксыл-кызгылт яр күренде, яр өстендә шакмак-шакмак йортлар күренде.* Н.Фәттах

**3.** *и. мәгъ. к.* **шакмаклы 2.** *Сөмбел, елмаеп һәм ялан аягына биек үкчәле сабосын киеп, кызчыклар шакмак-шакмак уйнагандагы шикелле, таштан ташка сикерекләп куйды.* А.Тимергалин

**ША́КТЫЙ** *рәв.* **1.** Гадәттәгедән артыграк, сизелерлек дәрәҗәдә, байтак. *Көннәрдән бер көнне шулай, кичке якта, без аның белән су буенда шактый озак йөрдек ---.* К.Миңлебаев. *Гомер буе яшәгән йортының шактый таушалган булуы Галимулла картның күптән эчен пошыра иде.* Э.Якупова

**2.** *с. мәгъ.* Күп. *Мин татар фольклористикасында шактый эш башкарган кеше.* Г.Әпсәләмов. *Куркытырга гына кирәк булыр, үлгән булып кыланырга. Коты алынсын. Тәүбәгә килсен. Ә анары, шактый вакыт узгач кына, күзне ачып, аны чиксез куандырырга.* М.Маликова

**3.** *хәб. мәгъ.* Күплекне, күп булуны белдерә. *Акылга муафикъ итеп, бүгенге фәнни терминологиягә таянып язылган бу китапның тарафдарлары шактый.* А.Тимергалин

**ШАКУ** *ф.* 1) Коры агач, таш кебек каты өслеккә бәреп, суккалап, коры, яңгыравыклы тавыш чыгару. *Җир өстеннән «тук-тук-тук» шакыган тавыш, аның артыннан археологлар хоры ишетелә.* И.Юзеев. *Салкын көзләр суык җилләренә Ирек биргән, тыеп тоткысыз. Бәрә, суга, шакый, дулый бу җил. Уйлый белми, нинди коткысыз.* Ф.Дәүләтгәрәева

2) *к.* **шакылдату** (*2 мәгъ.*). *Синсез дә, язсыз да калгач, Шәһәребез ятим. Тәрәзәмне җилләр шакый, Я, нәрсә дип әйтим?* Ф.Яруллин. *Кемдер килә дә ишек шакый, килә дә шакый.* Р.Вәлиев

**Шакый башлау** Шакырга тотыну. *Юматша ишекне дөбердәтә, тәрәзәне шакый башлады, ләкин аның чәбәләнүенә игътибар итүче булмады, троллейбус китеп барды.* Г.Әпсәләмов. *Кырыйдан икенче йортның болдырына менеп ишекләрен шакый башлаган*

*иде, өйалларыннан коточкыч калын тавышлы эт өреп куйгач, куркып кире китеп барды ---.* В.Нуруллин

**Шакый бирү** Бернигә карамый шакуын дәвам итү. *Шуннан ул тагы тәрәзә шакыды. Фахирәнең тавышытыны ишетелмәде. Фәйзулла аның саен шакый бирде.* М.Галәү

**Шакый тору** Шактый озак вакыт дәвамында шаку. *Шулай да мең ишекне шакый торгач, анысын таптык.* М.Зарипов. *«Җиде миллионлы халыкка китап чыгарырга тиеш бит без, нигә шуны белмәмешкә салышасыз?» – дип ишекләрне шакый торгач, Мәскәү агай кечелекле мөнәсәбәтен күрсәтеп алды.* М.Вәлиев

**Шакып алу** Бераз гына шаку. *Карандашы белән өстәлгә шакып алды да тагын кабатлады: – Иптәшләр, башлыйбыз...* Н.Фәттах. *Теге рядовой аларны, кулы белән генә ишарәләп, үз артыннан әйдәде дә, ишек янына килеп җиткәч, әүвәл колакларын торгызып бермәл тыңлап торды һәм кыюсыз гына шакып алды.* З.Хөсния

**Шакып йөрү** Озак, гел, теләсә кайда шаку. *Гел йөрде ул шулай өйдән өйгә, Гел чит ишекләрне шакып йөрде.* Ә.Рәшит. *Җен тәрәзә шакып йөргән, ди. Әкият дисәләр дә, белер хәл юк.* И.Диндаров

**Шакып калу** Берәр эш-гамәлдән соң да шакуны дәвам итү. *Зиннәт, бу «җен хатыны»ннан котылу өчен генә биргән кебек, күптәннән кесәсендә бөгәрләнеп йөргән унлыкны чыгарып тоттырды да --- комбайнына ашыкты, ә теге чегән хатыны күрше Илдарның тимер капкасын шакып калды...* Г.Гыйльманов

**Шакып карау** Сынау өчен шаку. *Өченче катка менеп, бүлмәсе ишеген ничә катлар шакып карадым.* А.Хәсәнов. *Иртәгесен Азат фатирының ишеге артында көчекнең өзгәләнеп шыңшуын ишеткәч, күршеләр ишекне шакып карыйлар.* А.Тимергалин

**Шакып китү** Үтеп барышлый шаку. *Хәзер менә кемдер шакып китте. Ни уй белән килгән ул бәндә?* Р.Фәйзуллин. *Ничә шакып китте инде җилләр, Кояш үзе кереп эзләде, Сине дәшеп зарыктылар гөлләр ---.* Ф.Яхин

**Шакып кую** Бер мәртәбә, кыска гына яки өзек-өзек шаку, кисәк шаку. *Ишек эчтән бикле иде. Егет сак кына бер-ике шакып куйды.* А.Гыйләҗев. *Рәфис каты гына итеп Шәмсүннең бүлмә ишеген шакып куйды.* А.Вергазов

**Шакып тору** Күпмедер вакыт дәвамында шаку; берөзлексез шаку; хәзерге моментта шаку. *Бакча туры, өй туры... Озак шакып тормады, Серенада җырлады...* Г.Афзал. *Авыл кешесе капка шакып тормас.* Р.Батулла

**Шакып узу** *к.* **шакып үтү**. *Күп тә үтми, Алексеевлар йорты тәрәзәсен кара кайгы шакып уза – Иван исемле уллары фашистлар белән тигезсез көрәштә батырларча һәлак була...* Ш.Мостафин

**Шакып үтү** Үтеп барышлый шаку; рәттән барысына да шаку. *Алай да ризалата алмагач, авылны аркылыдан буйга иңләп яңа йорт җиткерүчеләрнең капкаларын шакып үтте.* Р.Мөхәммәдиев. *Киткәнеңне белеп, азмы җилләр Шакып үтте минем капканы.* Р.Гаташ

**Шакып чыгу** Билгеле вакыт дәвамында өзлексез шаку; рәттән барысын да шаку. *Берәү «Илвина», «Илвина» дип, төн буена минем тәрәзәмне шакып чыкты.* Л.Ибраһимова

**Шакып яту** *сөйл. к.* **шакып тору**. *Мин шушылай фикер йөртеп яткан чакта, Тагын бер «изм» ишекне шакып ята!* Ш.Җиһангирова

**ШАКУЛ** *и. гар.* Төзү эшендә төгәл вертикальне билгеләү өчен, бау һәм шуның бер очына беркетелгән авыр предметтан гыйбарәт гади әсбап

**ШАКША** *и. фар. диал.* Дары яки тәмәке салып йөртү өчен гадәттә мөгездән ясалган кечкенә савыт. *[Егетләрнең зуррагы], кесәсеннән шакшасын алып, сул як кулының очына бер чеметемдәй насбай [алды].* М.Гафури

**ША́К-ШАК** *иярт.* 1) *к.* **шак-шок**. *Баскыч буенча шак-шак баскан аяк тавышы гына ишетелә иде.* М.Маликова. *Шулай икәүләп эшләп ятканда, останың ишеген шакыдылар: «Шак-шак-шак». Хатипның әтисе килгән. Бары ул гына шулай өч тапкыр шакый.* Н.Каштанов

2) Тешләрнең бер-берсенә бәрелү рәвешен белдерә. *Яралы үзе гыжгыж килеп сулыш ала, авызын аңсыз рәвештә ача, яба, тешләрен шак-шак китерә, шыгырдата.* Х.Камалов

**ШАКШАКАЛА** *и.* Күмәкләп уйнала торган балалар уены. *Качак-качак уйнау дисеңме, шакшакала дисеңме – берсен дә уйнамый калмады Галимҗан.* А.Расих

**ША́К-ШОК** *иярт.* **1.** Таш, агач, сөяк кебек каты әйберләр бер-берсенә яки башка каты өслеккә еш-еш яки әледән-әле бәрелүдән барлыкка килгән тавышны белдерә

**2.** *рәв. мәгъ.* Шундый тавышлар чыгарып; артык тавышланып. *Хуҗа кайтып килә, ахрысы, бүтәннәр текә баскычтан алай шак-шок менә алмас... Чыннан да, ишектән шат чырайлы, өр-яңа костюм кигән, ап-ак күлмәген килешле галстук белән бизәгән хуҗа килеп керде.* А.Гыйләҗев

**ША́К-ШОК ИТҮ** *ф.* Шакылдау. *Таш юлдан агач башмаклар --- шак-шок итәләр...* Р.Мостафин. *Элек, бухгалтер апалар шак-шок итеп счёт төймәләре тартып утырганда, аванс акчасын сәгатендә ала идек.* М.Юныс

**ША́К-ШОК КИЛҮ** *ф. к.* **шак-шок итү**

**ШАКШЫ** *с.* **1.** 1) Арусыз, пакь булмаган, пычрак. *– Суны каян алганнар алар? – дип сорый, ниһаять, Азат, бераз тынычлана төшкәннән соң гына. – Шул шакшы инештәнме?* А.Тимергалин. *Үтеп йөри торган бөтен җирләргә асфальт яисә таш җәелгән булганга, анда яңгырдан соң да бернинди пычрак, шакшы сулы күлдәвекләр юк.* А.Галимов

2) Керле, пычранган, берәр нәрсәгә буялган. *Хатын әйтә, алардан соң йортны тәртипкә китерергә ике тәүлек кирәк, ди, чөнки бөтен шакшы идәндә, учак кырында кала, шуларны җыяҗыя билләрем бетә, ди.* М.Мәһдиев. *Шул шакшы кулларың белән өстәл янына килергә ничек оялмыйсың?* Н.Фәттах

3) Калдыклар белән пычратылган, юынтык. *Шул коллектор буенча заводфабрикаларның шакшы сулары шәһәр читенә чыгарыла.* А.Алиш. *Дуңгыз фермасы авыл читендә булса да, аннан агып чыккан шакшы сыекча Каран суына ук барып төшә, аннары Каракүлгә әләгә...* А.Тимергалин

4) Тышкы күренеше, исе яки башка берәр ягы белән җирәндергеч, күңел кайтаргыч тоелган; нәҗес. *– Сыер савып, терлек тизәге түгеп, бәрәңгедән шакшы корт җыеп яшәү миңа батмый, сеңлем, – диде.* Н.Гыйматдинова. *Шул вакыт лекциям бүлмәсенә чирканчык шадра йөзле, шакшы күсе кыяфәтле бер адәм килеп керде.* Ф.Яхин

5) Чисталык сакламаган, гадәтендә пөхтәлек, чисталык җитмәгән, шапшак (кеше тур.). *Колхоз сыерларының имчәген төкереге белән юешләтеп сава иде, шакшы хатын ул, энем!* Н.Гыйматдинова

6) *күч.* Начар ниятле, вөҗдансыз, эчкерле, кабахәт (кеше тур.). *Хәер, шакшы күңелле әшәкедән яхшыны көтеп буламы?* М.Хуҗин. *Үз угланнарының*

*гомерен кыйдырткан бу адәм актыгы хәзер инде һәммә кеше өчен хәтта колхолоплардан да очсызрак бер шакшы җан иде.* В.Имамов

7) Намуссыз, оятсыз, яман, законсыз (эш-гамәл тур.). *Изге эшне шакшы чаралар белән якларга ярамый.* А.Тимергалин. *Урыслар үзләре дә, латышлар да, башкалар да армия фанатикларының нинди ялган һәм шакшы эшләргә баруын белеп торсыннар әле!* З.Зәйнуллин

8) *күч.* Әдәпсез, әшәке, сүгенүле, оятсыз (сүз, сөйләшү рәвеше һ.б.ш. тур.). *Ул тәрбияләнгән ятимнәр йортында, аннары ФЗӨ мәктәбендә шулкадәр шакшы телдә сөйләштеләр микәнни?* А.Тимергалин. *Ирена бик пар килгән усал, шакшы телле Хәмдүнә иренә, урлашуны, караклыкны яраткан ике улына авыл халкыннан сүз тидермәде.* Ф.Дәүләтгәрәева

9) *күч.* Кешенең шәхесенә тия, дәрәҗәсен төшерә торган, ялган, нахак (сүз тур.). *Минем әнине пычратмакчы буласыңмы шакшы телең белән?* Ә.Баян. *Алыгыз, истәлеккә саклагыз ул шакшы язмагызны.* Г.Әпсәләмов. *Ул вакытта бу дөньяны каралткан шакшы сүзләрдән күңелеңне ничек юып бетермәк кирәк?* Ф.Яхин

10) *күч.* Әхлаксыз, азгын, бозык (кеше тур.). *Мидхәткә Ленизаның җаны пычранган кебек тоела иде. Һәм ул бу шакшы хатын белән бер ятакта була алмый иде.* М.Маликова. *Берничә атнадан аның мәсхәрәләнгән гәүдәсен хәрби частьтан ерак түгел җирдән таптылар. Муенына «Синең йөрәгең батыр, тик күңелең шакшы» дигән язу тагылган иде.* Р.Сәгъди

11) *күч.* Гаделсез, гөнаһлы; күңелне кайтаргыч, биздергеч. *Тормышның тискәре, усал, шакшы яклары белән көрәшкәндә туңсам, арысам әгәр, шул рәхәт минутларны хәтерләп җылынам һәм көч җыям.* Г.Кутуй. *Бу шакшы дөньядан ак болытларга качып китсәң генә шул.* Ә.Галиева

**2.** *и. мәгъ.* 1) Кер, пычрак, пычрата торган нәрсә. *Саф алтынга шакшы буялмый.* Н.Әхмәдиев. *Җыен әтрәкәләмнең шакшысын юып ятарга мине әллә лашманчы карчыгы дип белдеңме?* А.Гыйләҗев

2) Гомумән эшкә, кулланылышка ярамый торган, зыянлы, пычрак һ.б.ш. көнкүреш яки җитештерү калдыклары, түгелә торган чүп-чар. *Кояш карны, пычрак дип тормый, ашый да ашый, юл чите көртләре кәрәзләнеп шыбырдап сөрлегәләр; яз шәһәрнең кыш буе җыеп, яшереп саклаган шакшыларын ача.* А.Гыйләҗев. – *Нинди шакшы ага сезнең цехлардан?.. – Кая шакшы? Бу суда балык үрчетеп була!* М.Маликова

3) Хайван яки кеше организмы эшчәнлегенең калдыгы. *Тәрәзәләргә чебен шакшылары катып беткән.* Ш.Камал. *Сыздың Берлинга таба, Юл буена корсагыннан Шакшысы тама-тама.* М.Җәлил

4) *күч.* Явыз ниятле, вөҗдансыз, эчкерле, кабахәт кеше. *Шакшы, син безне агач атка атландырырга маташма! Барып чыкмас!* Х.Камалов. *Рухы йомшакларга җил каршы. Язылмаган канун табигатьтә: Бер яхшыны таба бер шакшы.* Г.Сафин

5) *күч.* Әдәпсез, әхлаксыз, бозык кеше. *Бер дә бер көнне мәктәптә Сөярбикә (мөгаллимәнең исеме шулай иде) үзе генә калгач, тегеләр ишекне тыштан бикләп алалар: «Диненнән язган, явыз, шакшы!» – дип каргыйлар муллалар һәм көпә-көндез ут төртеп җибәрәләр.* Д.Бүләков

6) *күч.* Гайбәт, ялган, яла һ.б.ш. әшәке сүз, хәбәр. *Тарата ул аннан шул шакшыны, Чын хәбәр, дип, төрле җирләргә.* Ә.Исхак. *Болар особистлар лабаса! Хәрәкәттәге армиянең артыннан шакшы җыеп йөрүчеләр.* М.Әмирханов

7) *күч.* Гаделсезлек, хаксызлык, гөнаһ кебек күңелне кайтаргыч, биздергеч күренешләр, начарлык. *Шакшы белән тулган иске дөньядан Оҗмахлар ярату безнең эшебез. Чәчкәгә бөркәнгән олы Ватанның һәрбер кирпечендә кан һәм көчебез.* Х.Туфан

**3.** *рәв. мәгъ.* Чисталык, пөхтәлек сакламыйча, тиешле чисталык булмаган хәлдә. *Алла сакласын, шакшы торалар дип, бөтен дөньяга яманатыбызны таратыр.* К.Тинчурин. *Начар булма – яхшы бул, шакшы йөрмә – ару йөр, ди.* Г.Бәширов

**ШАКШЫЛАНДЫРУ** *ф. диал.* Шакшы итү, пычрату. --- *телебез булса, без менә ниләр сөйләр идек: ерткыч җанварларны аулаганчы, корткыч кешеләрне, табигать дошманы – браконьерларны, сулыкларны шакшыландыручы заводларның җитәкчеләрен аулагыз сез!* Р.Батулла

**ШАКШЫЛАНУ** *ф. диал.* 1) Буялу, пычрану, шакшы хәлгә килү. *Фәтхулла хәзрәтнең --- ашаганда, гадәте буенча, кычытмаса да, башын кашып шакшылануы, һәр аштан соң тарелкасын ялаган булып, бөтен сакаллары, борыннары белән майга манчылуы өй җәмәгатенә бик җирәнгеч тоелганлыктан, кызлар, бернәрсә дә ашый алмыйча, урыннарыннан ук торып киттеләр.* Ф.Әмирхан. *Чите төрле чүп-чарлар белән шакшыланган, өстендә зур-зур нефть таплары, фашист солдатларының мәетләре йөзгән пычрак Балтыйк диңгезе иде ул.* М.Мәһдиев

2) Шапшак кешегә әйләнү, чисталыкны сакламау. *Яшәсен кешечә, яшәсен безнеңчә! Эшләсен! Ничу шакшыланып йөрергә!* Л.Лерон

**Шакшыланып бетү** Нык шакшылану

**ШАКШЫЛА́У** *ф. диал.* Шакшы хәлгә китерү, пычрату. *Яхшы кеше халык рухиятен, табигатьне, гомумән җиһанны тазарта, ә яман кеше – шакшылый.* З.Мурсиев

**ШАКШЫЛЫК** *и.* 1) Чисталык булмау, антисанитария күренеше, берәр урын шакшы булу, пычраклык. *Бу кадәр хәерчелек, шакшылык, тәртипсезлекнең асылы нидән гыйбарәт? Милли сыйфатмы, әллә милли изелү сәясәте корбаннарымы? Сәясәткә сылтасаң, Айчибәрләр авылына кара: нинди чиста, төзек, матур.* Н.Әхмәдиев. *Бу кадәр тәртипсезлектән, шакшылыктан туеп, хезмәт күрсәтүче персонал төнгә үзләренең чиста почмакларына кереп кача, ахрысы.* Ф.Тарханова

2) Пычрак нәрсәләр, чүп-чар, калдык-постык; кер, пычрак. *Шакшылыктан арынган казаннар җиңеләеп калды, ләкин бу гына аз иде.* З.Мурсиев

3) Кешенең гадәтендә чисталык һәм пөхтәлек булмау, шапшаклык. *Борын эчендәге кутырны шакшылыктан күреп, янә бер тапкыр авырткан борынга чиертте.* Г.Кутуй. *Халыкның сырхаулавы да шушы шакшылыктан түгел микән?* З.Мурсиев

4) *күч.* Кеше характерындагы намуссызлык, түбәнлек, кабахәтлек кебек бик тискәре сыйфатлар, күңелендәге шундый тойгылар. *Хәсис икәнсең! Синең шакшылыгыңны моңарчы күрмәгәнмен!* М.Хуҗин. *Ә язучы кеше андый ук шакшылыкка чумуга, намусын тәмам югалтуга җөрьәт итә алмыйдыр.* Ф.Баттал

5) *күч.* Башка кешеләргә карата эшләнгән түбәнлек, әшәке гамәлләр. *Хәтер – һәр кешенең иң хәтәр дошманы, Шулдыр, күрәсең, безгә язмыш кушканы. Яшим, дисәң, уйлап кына яхшылыклар, Җанны телә искә төшеп*

*шакшылыклар.* Р.Ханнанов. *Аларның бөтен көче, энергиясе шакшылык, бозыклык эшләргә генә китә.* Р.Сәгъди

6) *күч.* Яла, әләк, нахак сүз, гайбәт. *Ләкин әчке ярсуы, бер гаепсез Рамилә адресына ыргытылган шакшылык һәм үзенең шушы мизгелдә чарасызлыгын, көчсезлеген тану Мөслимәгә карата күңелендә моңа кадәр яшәгән бар җылы хисен --- юкка чыгарып ташлаган иде.* Н.Әхмәдиев

**ШАКЫЛДАВЫК** *и.* **1.** 1) Бәргәләгәндә, әйләндергәндә, селкегәндә детальләре үзара бәрелеп яңгыравыклы шакылдау, шалтырау тавышы чыгара, кошлар куркыту, төнге каравылда сигнал бирү һ.б.ш. өчен кулланыла торган агач җайланма. *Мәктәптә дежур торулар күңелле булып китте: Югары очта да, Түбән очта да төнге каравыллар бар хәзер, урамга кайчан чыксаң да күңелне күтәреп шакылдавык тавышлары яңгырый.* А.Гыйләҗев. *Төн уртасы җиткәнне белдереп, шакылдавык кагып, каравылчылар үтеп китте.* Р.Сәгъди

2) Шундый ук җайланмадан гыйбарәт халык уен коралының бер төре

**2.** *с. мәгъ.* Шакылдый торган, шакылшокыл итеп торган

**ШАКЫЛДАВЫЧ** *и. к.* **шакылдавык**. *Мин шакылдавычымны алып чыгыйм әле, берьюлы урам әйләнеп кайтырмын.* Т.Гыйззәт

**ШАКЫЛДАТУ** *ф.* 1) Агач, таш, сөяк кебек каты өслеккә берәр каты әйбер белән бәреп, шак-шок иткән тавышлар чыгару. *Җил тәрәзә капкачларын каерып атарга теләгәндәй шакылдата, морҗада елый-елый сызгыра.* Г.Әпсәләмов. *Нәрсә бу, көрәк бик зур ташка тиде, ахры? Көрәге белән шакылдатып сугып карый.* А.Гадел

2) Берәр кеше утырган бүлмә яки яшәгән йортның ишегенә, тәрәзәсенә һ.б.ш.га кагып, керү теләге белдерү, чыгарга үтенү, берәр нәрсә турында сигнал бирү; шаку, кагу. *Тәрәзәләрен озак кына шакылдатсам да, җавап бирүче булмады.* А.Гыйләҗев. – *Шеф! – ярдәмче кинәт ишекне шакылдатмыйча йөгереп керде.* В.Исламетдин

**Шакылдата башлау** Шакылдатырга тотыну. *Шулай аптырабрак торганда, кинәт сул як шакылдата башлый.* Г.Ибраһимов. *Кичкә таба ишекне шакылдата башлады, тикшерүче янына илтүләрен сорады.* М.Маликова

**Шакылдатып алу** Аз гына шакылдату. *Шәүкәт чиләктән җиз чүмече белән кайнар ботка сосып алды да йоклаган малайның җиз күбәтәсен җиңелчә генә шакылдатып алды.* Н.Фәттах

**Шакылдатып йөрү** Озак вакыт шакылдату; шакылдату белән мәшгуль булу. *Төннәрен ирләр шакылдавык шакылдатып йөри. Малайлар аларга булыша.* Р.Идрисов

**Шакылдатып кую** Бер мәртәбә, кыска гына шакылдату. *Малай аптырап тормады, башларына иске оекбашлар, кәгазьләр шыплап тутырды да күн итекләрне шәпләп киеп җибәрде, үкчәләрен шакылдатып куйды ---.* А.Гыйләҗев

**Шакылдатып тору** Берөзлексез шакылдату яки әле, хәзерге моментта шакылдату. *Һашимов сүрән генә урынына барып утырды да, бермәлне сүз дәшмичә, карандашы белән өстәлгә җәелгән пыяланы шакылдатып торды.* А.Вергазов

**ШАКЫЛДА́У** *ф.* 1) Каты, коры яки туң нәрсәләрнең, бер-берсенә бәрелгәндә, каты өслеккә төшкәндә, шакшок иткән тавыш чыгаруы. *Мылтык сапларының идәнгә бәрелеп шакылдаулары, авыр ботинкаларның йөргәннәре ишетелде.* К.Нәҗми

2) *сөйл. к.* **шакылдату**. *Иске мәктәп кырмыска оясына охшап калган: тукылдаган, шакылдаган, кычкырган тавышлар ишетелә.* А.Гыймадиев

3) Үтәдән-үтә туңу, кату. *Баскан саен шакылдап торган туң җирдән күтәрелгән вак тузан өермәсе, әйләнеп-тулганып, битә килеп бәрә, әрсезләнеп күзгә, колак тишекләренә кереп тула.* А.Вергазов

**Шакылдап тору** Гел шакылдау, шакылдау гадәте булу; хәзерге вакытта шакылдау. *Башмак кебек ике эт пәйда була. Аларның теше кайчы кебек шакылдап тора.* С.Шәрипов

**Шакылдый башлау** Шакылдарга тотыну. *Аның чүкече шакылдый башлагач, Мәрьям чаршауның бер иңен шытырдатып тартып төшерде.* М.Маликова. *Сул як күршесе Тәкетдин карт уфалла арбасы янына чатанлап килде дә шакылдый башлады.* А.Хәлим

**ШАКЫ́Л-ШОКЫЛ** *иярт.* Әледәнәле, ритмлы рәвештә төрле югарылыкта чыккан шакылдау тавышын белдерә. *Менә залга профессор Сарыкаен шакыл-шокыл атлап килеп керде.* Р.Нуруллин. *Ишек дөңгелдәп ябылды, шакол-шокыл йозак бикләнгәне ишетелде.* Ватаным Татарстан

**ШАКЫ́Л-ШОКЫЛ ИТҮ** *ф.* Әледән-әле, ритмлы рәвештә төрле югарылыктагы тавыш чыгарып шакылдау

**ШАКЫ́Л-ШОКЫЛ КИЛҮ** *ф. к.* **шакыл-шокыл итү**

**ШАКЫРАЙТУ** *ф.* Бик каты туңдыру. *Көндез бик нык эретә. Төнлә шакырайтып туңдыра. Кар, пыяла кыйпылчыклары кебек, аяк астында шатыр-шотыр килә.* Х.Камалов. *Үткән атналарда шакырайтып туңдырганнан соң, ялан пыяла кебек ялтырап ята.* Д.Бүләков

**ШАКЫРАЮ** *ф.* 1) Үтәли туңу, кату, туңып бик каты хәлгә килү; шакылдау. *Әнә шул ватык «полуторка» аркасында юлда безнең барлык бәрәңгебез өшеп бетте, педучилищеда студентларга дип пешергән кәбестә ашында шакырайган берничә бәрәңге йөзеп йөри торган иде.* Г.Ахунов. *Көне буе чана шуып, шакыраеп каткан киез итекләребезне шакылдатмаска тырышып кына кердек тә ишек төбендә туктап калдык.* Н.Кәримова

2) Кибеп кату. *Үзле балчык утта шакыраеп каткан, чүлмәк төсенә кергән иде.* Р.Батулла. *Көздән тырмаланмыйча калган сарут камыллары шакыраеп кипкәч, тротуар читләреннән тузан исе күтәрелде.* К.Кәримов

3) Бик нык туңу, өшү (кеше тур.). *Өс киемнәреңнән котылсаң да, шыкраеп катарсың, чишенмәсәң, быкырдап төпкә китәрсең.* А.Гыйләҗев

**ШАКЫРДАТУ** *ф.* 1) Шыгырдату; шак-шок китерү, шакылдату. *--- ач бүреләр, көннең зәһәр суыгына түзә алмыйча, кич малга баруны исәпләп, шул карлы давыл эчендә караңгы төннәрне көтеп, тешләрен шакырдатып йөриләр.* Г.Ибраһимов. – *У-у, боза-ау! – диде Ислам, тешләрен шакырдатып.* Н.Фәттах

2) Үтәдән-үтә туңдыру, нык катыру. *Көннәр дә һаман килде-китте: кичтән генә җылыта, ә таңга шакырдатып туңдыра.* С.Шәрипов. *Көз бозлы таягы белән «орды» да, шакырдатып, ирне туңдырды.* Н.Гыйматдинова

**ШАКЫРДА́У** *ф.* 1) *к.* **шакыраю**. *Шунысы гына мәзәк: салкын көннәр җиттеме, кое шакырдап туңа да кызганыч дәрәҗәдә серсез булып кала.* Ә.Баян. *Хәтимә апа толыбын, салып, Тайбәттәйгә киерткән дә үзе юл буе җилдә шакырдап кайткан.* Л.Ихсанова

2) *к.* **шыгырдау**

◊ **Шакырдап торган** Чатнама, шартлап торган, үзәккә үтә торган. *[Тышта] шакырдап торган суык.* И.Салахов

**ШАКЫ́Р-ШОКЫР** *иярт.* Зур, авыр таш, тимер кебек каты әйберләр бер-берснә ышкылудан, бәрелүдән барлыкка килгән тавышны белдерә. *Яшел вагоннар буферларын шакыр-шокыр чәкешеп туктый башлауга, алдагы вагоннан бер кыз, җилдәй очынып, җиргә сикерде.* Г.Мөхәммәтшин

**ШАКЫ́-ШОКЫ** *иярт.* **1.** *к.* **шак-шок**. *Иртән дә кага, көндез дә кага, карыны ачса, аяк өсте генә капкалап чыга да яңадан шакы-шокы, шакы-шокы, шакы-шокы...* Г.Сабитов

**2.** *рәв. мәгъ.* Шак-шок иткән тавыш чыгарып, шакылдап. *Вагонда шакы-шокы кайту Фәниярга шактый газап, авырту китерсә дә, аның күңеле шат күренә.* Ф.Яруллин. *Вагон тәгәрмәчләренең шакы-шокы дөбердәп баруы тычкан кетердәткән кебек кенә тавышны якында ятучылар да ишетмәслек итеп басып китә...* И.Сираҗи

**ШАКЫ́-ШОКЫ КИЛҮ** *ф.* Шакылдау, шак-шок иткән тавышлар чыгару. *Бабамның да ишегалдында шакы-шокы килгәне ишетелми, эчке яктан әбиемнең дә табак-савыты шалтырамый.* Ф.Сафиуллин

**ШАЛАВАН** *и. гади с.* Сөйләмчәк һәм мәзәкчән, шаян, шук кеше. *Малай минем телсез. Аның авызыннан сүзне келәшчә белән тартып алырга кирәк, ә киленем үзем кебек шалаван.* Ф.Хөсни. *Җыл башында тудым. Мин шалаван идем.* Милли-мәдәни мирасыбыз

**ШАЛАГАЙ** *с. сөйл. к.* **шалапай.** *Шалагай малайлыктан чыгу*

**ШАЛАГАЙЛАНУ** *ф. сөйл.* Бернигә дә җитди карамыйча, күңел бирмичә тик йөрү, эшсез йөрү. *Гәрәй – молодец, ичмасам, шалагайланып, шар сугып йөрми, басуга күз-колак булып тора.* М.Шабай

**ШАЛАГАЙЛЫК** *и. сөйл. к.* **шалапайлык**. *Малайдагы шалагайлык*

**ШАЛАМА** *с.* **1.** 1) Сәләмә, нык искергән, таушалган, җимерелгән, теткәләнеп беткән. *Игътибар беләнрәк карасам, тәрәзәдән төшкән сүрән ай яктысында, аяк очымда, сәкедә, шалама бишмәтенә төренеп, балаларның берсе утыра.* А.Шамов. *Әмма дә берсе тузгак чәчле, шалама киемле һәм бик шапшак.* Т.Нурмөхәммәтов

2) Йоны, каурыйлары тигезле-тигезсез булган, йолкынып, коелып беткән, төрле якка тырпаеп торган; йолкыш (хайваннар тур.). --- *бакчада чияләр кызарып килә; бер шалама чыпчык үзенең балачыгын очарга өйрәтә* ---. И.Гази. *Теге шалама песи һаман мыраулап йөри.* А.Гыйләҗев

3) Йолкыш, бик ярлы кыяфәтле. *Өченче көн базар аша узып барам, каршыма шалама гына бер хәерче килә.* А.Гыйләҗев

4) *күч.* Дәрәҗәсез, абруйсыз, әһәмиятсез, килде-китте, юк-бар (кешеләр тур.). *Ул кызда безнең халыкка хас тыйнаклык юк... Әтисе күк шалама тургай булыр, җырлап көн уздырыр...* А.Гыйләҗев

**2.** *и. мәгъ.* 1) Берәр иске нәрсәнең, гадәттә кием-салымның калдыклары, кисәкләре. *Анда, шаламалар арасында, жиде-сигез яшендәге бер малай белән бер кечкенә кыз ята икән, – ут яктысында күзләре генә җемелди.* А.Шамов. *Вәзыйх, ара җайлана башлаганга куанып, тарантас төбенә салырга иске юрган шаламасын култыгына кыстырып, тышка атылды.* Х.Камалов

2) Гомумән иске, җимерек һ.б.ш. әйбер. *Ул өйне җиһазлыйсы да бар бит әле. Өр-яңа бүлмәгә яшьләр тулай торагына тыгынчыклап тутырылган шаламаларны илтеп куймассың бит!* К.Тимбикова

3) *мыск.* Килде-китте кеше. *Коля, шаламаларыңны җый да тай әле моннан.* Р.Сәгъди

4) *күч.* Искелек, артта калганлык, кирәксез, алдынгы булмаган күренеш. *...Кирәк безгә яңа фөнүн. Яхшы тәртип, тугры канун. Бетсен иске шаламалар. Корыйк гүзәл яңа тормыш.* Җыр

**ШАЛАМАЛАНУ** *ф.* Сәләмәләнү, нык таушалу, теткәләнеп бетү

**Шаламаланып бетү** Нык шаламалану. *Менә капчык киндереннән тегелгән, шаламаланып беткән күлмәк кигән Эзоп.* Ю.Сафиуллин

**ШАЛА́НДА** *и. фр.* 1) Судноларга йөк төяү-бушату һ.б.ш. өчен кулланыла торган кечерәк баржа. *Җиңел яхтага таба капчык-капчык ком төягән шаланданың баруын күргәч, яр буендагы ачык авызлар һәм матрослар шактый гаҗәпләнделәр.* А.Толстой. *Мәрхүм Әхмәт һәм Фатех абзыйлар, төн йокламыйча, мәчет төзелешенә шаландалар белән Чабаксардан таш ташыдылар.* О.Хөсәенов

2) Башлыча Кара диңгездә яссы төпле, җилкәнле һәм ишкәкле балыкчы көймәсе. *Эх, хәзер менә шаланда булсын иде, шаланда!* Г.Минский. *Җитәм! Әгәр инде арысам, хәлдән тайсам, диңгез өсте балыкчыларның җилкәнле шаландалары белән тулы. Баркасларына алар алырлар.* А.Хәсәнов

**ШАЛАПАЙ** *с. сөйл.* **1.** Җиңел холыклы, бернәрсәгә дә җитди карамаган, игътибарсыз, төгәллексез; җилбәзәк, җилкуар. – *Шалапайрак бәндә булып чыкты шул, – дип, авыз эченнән генә мыгырданып җавап кайтарды ул.* Н.Акмал. – *Төрттеләр миңа ут, әнәтерәк шәһәрдән кайткан шалапай малайлар шырпы ташлады.* Н.Гыйматдинова

**2.** *и. мәгъ.* Шундый холыклы кеше. *Теге шалапай һаман бимазалап кына тора.* Ә.Хәсәнов. *Шуннан Фираяга әндәштеләр: – Кызым, бар әле шул шалапайга ботка салып бир.* Д.Бүләков

**ШАЛАПАЙЛАНУ** *ф. сөйл.* Холкы белән шалапайга әйләнү; үзен шалапайларча тоту, шалапайлык күрсәтү

**Шалапайланып йөрү** Озак вакыт яки шушы араларда шалапайлану

**ШАЛАПАЙЛЫК** *и. сөйл.* Җиңел холык, эш сөймәү, эшсезлек, мәнсезлек. *Без югары әхлак кешеләре булырга, төпле, акыллы, тәртипле булырга тиешбез. Шалапайлык, кылану безгә батмый.* Т.Галиуллин. *Егетләргә дә әйтеп куйган идем: «Шалапайлык булмасын! Дисциплина армиядәге кебек булсын», – дип.* Р.Хисаметдинов

**ШАЛАШ** *и.* Колга, агач ботаклары, камыш һ.б.ш.дан печән, салам кебек нәрсәләр каплап ясалган зур булмаган вакытлы корылма. *Егетләр, дәррәү кубып, палатка белән янәшә генә ылыс ботакларыннан шалаш кордылар.* А.Хәсәнов. *Шалаш алдында, коры печәндә, имеш, елмаеп, Уфа кызы Былбыл утыра.* Н.Фәттах

**ШАЛДЫР** *иярт. к.* **шалтыр**. *Шалдыр итеп килеп, трантас ишек төбенә туктады.* Г.Исхакый. *Трамвайда барганда Шалдыр, шолдыр, шалдыр... Алдыр, энем, алдыр, Күңелләрне талдыр ---.* Г.Афзал

**ШАЛДЫРАВЫК** *с.* **1.** *к.* **шалтыравык**

**2.** *и. мәгъ. күч.* Моңсыз, аһәңсез, җыр, көй, музыка әсәре. *Эстрадабызны җыен булыр-булмас текстка көйләнгән, бернигә ярамаган музыкаль шалдыравыклар каплап алды.* Мәдәни җомга

**ШАЛДЫРАВЫКЛЫ** *с. к.* **шалтыравыклы**. *Сүз булсын өчен генә сөйләнә торган һәм мәгънәсез, һәм риялы сүзләр, төшләре алынып ташланган чикләвек кабыклары шикелле, шалдыравыклы, ләкин кирәксез нәрсәләр иде.* Ф.Әмирхан

**ШАЛДЫРА́У** *ф. к.* **шалтырау.** *Озак та үтмәде, ханның капкалары шалдырап ачылды, зиннәтле аргамаклар өстендә хан, шаһзадәләр һәм иң алда Тойгы туташ килеп чыкты.* Н.Думави

**ШАЛДЫРТ** *иярт.* Әйбер кисәк төшеп, тәгәрәп яки бәрелеп барлыкка килгән, башта яңгырап китеп, соңыннан өзелгән тавышны белдерә

**ШАЛДЫРУТ** *и. бот.* Сыраҗчалар семьялыгыннан туры сабаклы, чукланып торган башаксыман чәчәкле, өлгергән орлыклары селкеткәндә шалтырый торган берьеллык ярымпаразит үлән үсемлек; шөлдерут; *русчасы:* **звонец, погремок**

**ШАЛДЫ́Р-ШОЛДЫР** *иярт. к.* **шалтыр-шолтыр**. *Көймәдән төшеләр, ярга менделәр һәм, шалдыр-шолдыр селкенеп йөргән трамвайга утырып, шәһәргә кайтып киттеләр.* *Ә.Еники.* *Трактор, кара төтен ургытып, каты гына такылдап алды да кинәт тартылып куйды һәм, җир өстенә капланып яткан очлы тешле тырмаларны өстерәп, шалдыр-шолдыр кузгалып та китте.* Н.Фәттах

**ШАЛКАН** *и. фар.* 1) Әвернәчәчәкләр семьялыгыннан аксыл сары чәчәкле, сары яки ак төстәге итләч тамырлы икееллык яшелчә үсемлек. *Түтәлләрдә җәй буе кишер, шалкан үсә.* А.Гыйләҗев. *Их, Сәйфи, Сәйфи, үзең акыллы адәмгә охшап торасың. Шалкан чәчеп баеган кешене күргәнең бармы?* Т.Галиуллин

2) Шул үсемлекнең ашарга яраклы йомры тамыры. *Син шул малайлар белән кеше бакчасыннан шалкан урлаудан бүтәнне белмисең.* Ф.Яруллин. *Кадыйров капчыгында бер шалкан, икенче берәүнең чикләвек зурлыгында гына берничә бәрәңгесе табыла.* Р.Мостафин

◊ **Шалкан бәясе** Бик арзан хак, ныкочсыз, бер дә кыйбат түгел. *Американың күптән түгел генә үлгән мультимиллионеры Арманд Хаммер ул елларда --- Россиянең гаҗәеп байлыкларын, сәнгать әсәрләрен шалкан бәясенә алып чыгып киткән була.* М.Галиев. *Синең акыллы киңәшеңне тыңлап, без бу кунгасны шалкан бәясенә генә сатып алдык.* С.Сабиров. **Шалкан кебек** 1) Таза, сәламәт, тыгыз тәнле. *Кызымны да бүләккә күмеп бетердем. Түтәлдән генә казып алган шалкан кебек тыпырдап торган сау-сәламәт бала алып кайтканы өчен.* А.Хәсәнов. *Әнә, үзем дә «хәчтеруш» дип әйтеп салдым шалкан кебек энемә. Әй, яратып кына бит.* Г.Якупова; 2) Ап-ак. *Искәндәребез безнең ошатмаслык түгел шул, әрчелгән шалкан кебек ап-ак тәнле, күлмәк кидерткәндә ялгыш муенына кулың кагылып китсә, шырык-шырык көлергә тотына.* Ф.Яруллин. [Бану:] *Бер кисәк исле сабын бетердем инде, файдасы бармы? [Саҗидә:] Битең шалкан кебек булган инде. [Хәдичә:] Чөгендер кебек диген! Кып-кызыл бит!* Н.Кәримова. **Шалкан мае** Әрекмән тамырының минераль вазелин маендагы төнәтмәсеннән гыйбарәт косметик матдә; *русчасы:* **репейное масло**. *Миңсылу, шалкан мае белән майланган, иске пумала шикелле чәчен ике толым итеп, яшел тасма белән урап, өстенә соңгы мода энҗеле калфакны да куйды.* К.Тинчурин. *Нишләргә дә белгән юк – чәч коела, маңгай киңәя, баш түбәсе такырлана. Кызларның миңа карап аһ итмәүләрен шуннан күрәм. Кычыткан төнәтмәсе белән дә юып карыйм, шалкан мае да сөртәм ---.* А.Хәмзин. **Шалкан суы** Туклыксыз, сыек, тәмсез шулпа. *Бер чүмеч шалкан суы – әшәке баланда өчен бер-берсен этешептөртешеп беттеләр, бер-берсенең кулыннан табакларын, консерв банкаларын тартып алдылар.* Г.Әпсәләмов. **Шалкан шулпасы** *к.* **шалкан суы**. *Икенче көнне, караңгы төшкәч, Йозеф бер котелок баланда – шалкан шулпасы алып килде.* Г.Әпсәләмов. **Шалкан чәчерлек булу** Бик күптән юынмау, керләнү, пычрану, тузан утыру. --- *колак тишекләренә шалкан чәчерлек булган, ямаулы ыштан кигән сагызлы чәчле малаеның кулына кабартма кисәге тотып урамга чыкканына тап булган әти кеше болай гына, бәхете ташыганнан гына әлеге сагызлы башка берне биреп ала – ризыкның кадерен бел!* М.Мәһдиев. *Тырнагың киселгән булсын. Колагыңа шалкан чәчерлек булмасын. Якаң керләнмәсен.* А.Тимергалин

**ШАЛТ** *иярт.* **1.** 1) Каты әйберләр бер-берсенә кисәк шапылдап бәрелгәндә барлыкка килгән тавышны белдерә. *Барлас авызын җиң очлары белән генә ышкып алды да, пәкесен шалт иттереп ябып, кесәсенә салды.* Н.Дәүли. *Колхозыңда эш барамы-юкмы, бухгалтериядә көне-төне чут сугалар: уңга төймәләрне шалт, сулга төймәләрне шалт!* Н.Әхмәдиев

2) Берәр эш-гамәлнең кәтелмәгәндә, кискен хәрәкәт белән, бик тиз, кыю итеп башкарылу рәвешен, кисәк килеп чыгуын һ.б.ш.ны белдерә. *Сый-мазар юк инде, гафу! Кунаклар чакырганны искә төшереп, кибеткә йөгереп барсам, шалт, ябып куйганнар, чукынганнар.* И.Юзеев. *Кызларның капкадан килеп керүе була, шалт салкын су болар өстенә.* Ф.Яруллин

3) Кисәк китереп сугу, бәрү, ату рәвешен белдерә. *Анда күп сөйләшеп тормыйлар. Алып чыгалар да шалт маңгаеңа берне!* А.Хәсәнов. *Шуннан үзе сизми дә кала – шалт тимерчыбык моның кулына.* Г.Мөхәммәтшин

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Кисәк, кискен хәрәкәт белән. *Мин, шалт борылып, кереп тә киттем. Бар да басып катып калды.* Ю.Сафиуллин

2) Бик җиңел итеп, авырсынмыйча, бик тиз генә. *Менә күрерсез, Карелия тайгасына аяк кына басыйк, мин сезгә бер карт Топтыгинны шалт аударып бирәм.* А.Хәсәнов

**3.** *хәб. мәгъ.* 1) Эш-хәрәкәтнең көтелмәгәндә, кисәк, бик тиз башкарылуын белдерә. *Тәнкыйтьченең дә ниндие бар да ниндие юк. Берәр уртача роман чыктымы, шунда ук уртача мәкалә – шалт!* Н.Нәҗми. *Зәйтүнә йоклап китүгә, әкрен генә үрмәләп киләсең дә чәченнән таракны шалт!* Н.Кәримова

◊ **Шалт берне!** Кисәк яки каты итеп сугып, бәреп җибәрү турында. *Узып киткәч, артыннан килдем дә утын агачы белән шалт берне түбәсенә.* З.Мәхмүди. **Шалт итеп** 1) Кисәк, уйламаган җирдән. *Кемгәдер охшаган бит бу. Шалт итеп искә төште. Яшь чакта яратып йөргән марҗам Маруськаның игезәге ләбаса!* Т.Миңнуллин; 2) Берәр эш-хәрәкәт бик тиз, төгәл, җитез, җиңел башкарылу турында. *Барына да дүрт сутый шалт итеп бүлеп куелган, койма белән әйләндерелгән.* Э.Яһудин. *Тегеләрнең җавап биргәнен дә көтмичә, тәрәзәне тартып ача да саңаклары селкенеп торган тере балыкларны шалт итеп тәрәзә төбенә китереп сала.* М.Зарипов; 3) Төп-төгәл, таман. *Менә, гөлкәем, бот сөягең оясыннан чыккан. Хәзер без аны шалт итеп урынына утыртып куярбыз.* Ф.Яруллин. **Шалт иткән** Өр-яңа; югары сыйфатлы, бар ягы да килгән; бик таман, төп-төгәл туры килгән. *Әмма бездә бик сирәк авиакомпания яңа шалт иткән очкычлар белән мактана ала.* Р.Бикмөхәммәтова. **Шалт, Мөхәммәтҗан**! Берәр эш-гамәлнең, вакыйга-күренешнең бөтенләй көтелмәгән, логикасыз, сәер, көлке һ.б.

булуы турында. *Кай ара акча җыйган бит, Дача салдырып куйган бит, Шалт, Мөхәммәтҗан!* Ш.Галиев. *Маяковскийның тыелган ике шигырен укыганыем. Шалт, Мөхәммәтҗан, ун ел Магадан лагерьлары.* А.Хәсәнов. **Шалт та шолт** *к.* **шалт-шолт**. *Нинди егет ул, наган тагып, сөйгән кызы янында шалт та шолт атып йөргән?* М.Мәһдиев. *Ул ипи салган сумкасын кухняга ыргытты да, өермәдәй бөтерелеп, эчке бүлмәгә кереп китте, аннары кире чыгып, ванна, караңгы бүлмә ишекләрен шалт та шолт ачып япты.* М.Маликова

**ША́ЛТ ИТҮ** *ф.* Шалт сыман тавыш чыгару. *Пароходтан аткан бауның чукмарлы башы пристань стенасына шалт итеп бәрелде.* И.Гази. *Ул чут төймәсен тагын шалт итеп китереп салды, канәгатьләнү белән елмайды.* М.Мәһдиев

**ША́ЛТ-ШОЛТ** *иярт.* **1.** Берәр каты нәрсәнең әле бер төрле, әле икенче төрле итеп, кабат-кабат кисәк килеп бәрелүеннән барлыкка килгән саңгырау тавышны белдерә. *Бухгалтер гына бит ул... шалт-шолт, шалт-шолт...* И.Юзеев. *Шалт-шолт – касса аппараты чутлап акчаны йота, бәхетле бәндә алган әйберен барып кочаклый, машинага күчереп зык куба, соңгы чиктә калган тиененә берәр яртылык җыешта.* К.Кара

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Шундый тавыш чыгарып. *Ишек төбендә торучы ишекләрне япты, шалт-шолт иттереп бикләп тә куйды.* Н.Дәүли. *Тагын өстәле янына атылды, тартмаларны шалт-шолт ачып япкалый башлады.* Г.Әпсәләмов

2) Бик җәһәт кенә, оста, җайлы итеп. *Менә бу коралны карагызчы: балтасы, пычкысы, көрәге, өтергесе бар – кнопкасына басасың да шалт-шолт алыштырып кына куясың.* А.Тимергалин. *Зоотехник ат янына килергә куркып торганда, җырчы Салават абый килде дә шалт-шолт укол кадап чыкты.* Р.Батулла

**ША́ЛТ-ШО́ЛТ ИТҮ** *ф.* Шалт-шолт кебек тавышлар чыгару. *Бухгалтер --- урынына килеп утырды. Счёт төймәләре шалт-шолт, шалт-шолт итә.* А.Ганиев

**ША́ЛТ-ШО́ЛТ КИЛҮ** *ф. к.* **шалт-шолт итү**. *Тукучы Бабикинаның станогы бик барахлит итә, шалт-шолт килә, җепне өзә, көн буе тукыганы 12–15 метр.* И.Гази

**ШАЛТЫР** *иярт.* **1.** Берәр буш, куыш әйбер төшеп яки бәрелеп тәгәрәп киткәндә, пыяла ватылганда барлыкка килгән һ.б.ш. яңгыравык тавышны һәм шалтырау рәвешен белдерә. --- *Камил абый тотып торган букән туп урынына атылып тә китте. Баштагы мәлдә сызгырган тавыш кына ишетелеп калды, бүкән мунча тәрәзәсен шалтыр иттереп, эчкә кереп юк булды.* Ф.Сафин. *Трамвай килә, урам-йортлар тетри, Селкенә ул, шалтырр, тиз йөри, Тукталышын үтеп китте бере, Икенчесе әле күренми...* Ф.Яхин

**2.** *с. мәгъ.* Шалтырый торган. *– Шушы шалтыр арбаң белән космоска очырасың бит инде! – дип, Хафизны орышырга керешә.* А.Хәсәнов

**ШАЛТЫРАВЫК** *с.* **1.** 1) Шалтырый торган, шалтырап тора торган

2) Селкенеп, чайкалып, калтырап тора торган. *Шунда товар ташучы поездның бер шалтыравык вагонына эләктем дә Урыссуга элдерттем.* Ф.Яруллин

3) *күч.* Сөйләмчәк, күп сөйләшүчән; мәзәкчән. *Арбадан шулай тиз генә төшкәнгә, шалтыравык Равил белән шулай тиз генә аерылышканга бераз моңсу да, авыр да кебек.* Н.Фәттах

4) *күч.* Мактанчык, шапырынучан. *Минем бик зур бер кимчелегем бар: мин тормышны һәм безнең киләчәкне шактый тирән итеп аңлый белам, мин тар фикерле дә, вак та, коры шалтыравык кына кеше дә түгел.* Г.Бәширов. *Безнең заманда борчуга, моң-сагышка урын юк, кеше гел куанып, көлеп-биеп, җырлап кына яшәргә тиеш дип уйлаучы шалтыравык оптимистлар бик ялгышалар.* Г.Әпсәләмов

5) *күч.* Буш, мәгънәсез, файдасыз. *Ясалма пафостан, шалтыравык буш сүзләрдән бик сакланганга, гадиләрен тиз генә таба алмады, икенче яктан, профессорлар алдында артык авылча күренүдән курыкты.* Г.Әпсәләмов. *Намуссызлык тыштан никадәр ялтыравык булмасын, эчтән шалтыравык ул.* Г.Хөсәенов

**2.** *и. мәгъ.* 1) Бәрелгәндә, сугылганда шалтырый торган куыш, буш предмет. *Чит илдә эшләнгән таза тимерле машинаны калай мичкәләр вата-җимерә алмаса да, янга, артка чигенүчегә комачау ясарлык кына көч бар иде ул шалтыравыкларда.* Т.Галиуллин

2) Читенә шөлдерләр тезелгән кыршау яки кечкенә барабан формасындагы бәрмә уен коралы; *русчасы:* **бубен**. *Бер чегән шарманщигы, янында шалтыравык тоткан чегән хатыны, артларыннан бер көтү бала шаулашып йортка керәләр.* Ф.Сәйфи-Казанлы

3) Селкеткәндә, кагылганда эчендәге вак нәрсәләр шалтырый торган куыш балалар уенчыгы; *русчасы:* **погремушка**

4) *к.* **кыңгырау** (*3 мәгъ.*). *Тавыш, якыная-якыная, безнең тугрыга килеп җитте. Инде моңлы җыр тавышы җиренә ишегебезнең шалтыравыгының тавышын ишетә идек.* С.Гыйффәт

5) Халыкка хас булмаган, яңгыравы матур тоелмаган уен коралы яки музыка уйнату җиһазы. *И-их, гармунда уйнасаң икән син. Бу шалтыравыгың күңелне кытыклап кына уза бит ул. Ә гармун бар хәсрәт-кайгыңны актарып чыгара.* Р.Вәлиев

6) *күч.* Буш сүз сөйләргә, шапырынырга яратучы, мактанчык кеше. *Фырт машиналарда йөргән егетләрне мин буш шалтыравыклар гына дип уйлый идем.* Ф.Яруллин. --- *үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртып яшәүче, әмма дә ләкин күкрәк киереп, олы язучы кыяфәте чыгарып йөрүче шалтыравык калай әтәчләр шактый гына очрап торса да, Рафаэль Мостафин кебекләр, чыннан да, күп булмады* ---. Р.Миңнуллин

7) *күч.* Буш сүз, коры мактану; бернинди әһәмияте, мәгънәсе, файдасы булмаган, сүз өчен генә эшләнгән эшгамәл. *Бөтен хезмәт бушка китте. Биш яңа образ эшләрлек вакытыбызны шушы шалтыравык эченә тыктык.* Ю.Сафиуллин

**ШАЛТЫРАВЫ́К ЕЛАН** *и. зоол.* Караеланнар семьялыгыннан койрыгы очында мөгезсыман бөҗралардан торган шалтыравыгы булган, дошман якынлашканда шуның белән сигнал бирә торган агулы елан; *русчасы:* **гремучая змея**

**ШАЛТЫРАВЫКЛЫ** *с.* 1) *к.* **шалтыравык 1.** *Балаларны күп вакытта үсемлекнең җимешләре – шалтыравыклы серле капкачлы тартмачыклары, ашарга тәмле майлы орлыклары җәлеп итә.* Агулы үсемлекләр

2) Берәр төрле шалтыравыгы булган

3) *күч.* Табигый булмаган рәвештә яңгырап, чыңлап чыга торган (тавыш тур.). *Камышлар арасында кемдер гакылсыз рәвештә кычкыра, нindидер ят һәм ярык, шалтыравыклы тавыш белән тотына алмый көлә башлады: – Ха-ха-ха-ха!* Һ.Такташ

4) *күч.* Файдасы, мәгънәсе, гамәли әһәмияте булмаган, буш, мактану, масаю, шапырынуга кайтып калган. *Ләкин шулкадәресе дә бар: еллар үткән саен, андый шалтыравыклы,*

*ялтыравык сүзләр, авыз суларын корытып бәхәсләшүләр үзләренең кызыгын югалтты*. М.Хәсәнов. *Ахыр килеп, югары шигъри өслүп хәрби уеннарга багышланган шалтыравыклы чакырулар белән алышынды*. Э.Халидов

**ШАЛТЫРАК** *и. к.* **шалтыравык**. *Эчкәннең теле шалтырак, үзе калтырак*. Мәкаль

**ШАЛТЫРАТУ** *ф.* 1) Тимер, калай һ.б.ш.дан ясалган әйберләрне берберсенә орындырып, бәргәләп, суккалап, шалтырау тавышы чыгару, шалтыр-шолтыр китерү. *Ул да түгел [машина], әрҗәсендәге сөт флягаларын шалтыратып килеп тә җитте*. Ә.Хәсәнов. *Операция сестрасы зур ак эмаль тазга шалтыратып инструментларны тутыра башлады*. М.Маликова

2) Телефон челтәрендә номеры булган билгеле абонент белән элемтәгә керү өчен, аның номерын җыеп, сигнал бирү. *Прокурорның үзенә үк шалтыратасың калган*. Ә.Сафиуллин. *Бер номерга шалтыраттым. Трубканы ир-ат алды*. Ж.Гасыймова // Берәр кеше белән телефон ярдәмендә элемтәгә кереп сөйләшү, хәбәрләшү, аралашу. *Яңгура берничә тапкыр телефоннан шалтыратты, аннары үзе дә гостиницага килеп чыкты*. Г.Әпсәләмов. *Дженет миңа көн саен диярлек шалтыратып тора: хат килсә-нитсә, берүк шул көнне үк безгә китер, ди*. Ф.Яруллин

**Шалтырата башлау** Шалтыратырга керешү. *Алексей Лукич, әрнеп: – Мин дә бит кеше, минем дә нервыларым бар, минем дә вакытыннан элек инфаркт аласым килми, – диде. – Иртән иртүк шалтырата башлый да кичкә кадәр ээзәрлекли*. Г.Әпсәләмов. *Белеп торам: ярты минуттан әни пыр туздырып шалтырата башлаячак*. А.Әхмәтгалиева

**Шалтыратып алу** Тиз генә шалтырату. *Аш кайнаган арада, тулай торакка шалтыратып алырга булды*. Ф.Яруллин. *Бәхетенә, Казанга оча торган рейска да өлгерде. Үзен каршы алуларын үтенеп, апасына шалтыратып алырга да онытмады...* Г.Габидуллина

**Шалтыратып йөрү** Һәрвакыт, һәркайда, озак вакытлар шалтырату. *Артында хатының табак-савыт шалтыратып йөргәндә, ничек язасың инде, ди*. Л.Ихсанова. *Кадровыйлар армия юбилее медален, яшел материалдан, сап-сары сызык үткән БАМ медален, тегенди-мондый значокларын шалтыратып йөргән булалар*. С.Шәрипов

**Шалтыратып карау** Сынау, белү, тикшерү өчен шалтырату. *Район сельпосына шалтыратып та карадым, андый товарлар хәзергә бездә юк, диләр*. Т.Гыйззәт. *Алай да йөрәге түзмәде, Ләйләләрнең өенә шалтыратып карарга булды*. Ф.Бәйрәмова

**Шалтыратып кую** Алдан шалтырату; бер мәртәбә, кисәк шалтырату. *Кереп кунарга урыныгыз булмаса, мин Сезгә бу хат белән берничә адрес җибәрәм. Аларга мин телефоннан шалтыратып куйдым: бу мәсьәләдә Сезгә кыенлыклар булмас*. Ф.Яруллин

**Шалтыратып тору** Даими рәвештә, еш, әледән-әле яки хәзерге моментта шалтырату. *Врачларга шалтыратып торганда гына, Айтуган абыйлар килде*. Ф.Яруллин. *Барыгыз, кайтыгыз, ярты сәгать саен шалтыратып торыгыз, дип, дежур врач телефон номеры белән бергә күңелемә шом салып кайтарып җибәрде*. Бу тормышта ниләр бар?

**Шалтыратып чыгу** Билгеле вакытның башыннан ахырына кадәр шалтырату; һәрберсенә берәм-берәм шалтырату. *Шәһәрнең бөтен милиция бүлекләренә шалтыратып чыкты ул*. Л.Ихсанова. *Көне буе танышларга, дусларга шалтыратып чыктым, телефонның акчасы беткәч кенә туктадым*. Р.Вәлиев

**Шалтыратып яту** *сөйл. к.* **шалтыратып тору**. *Кабаланып, бөтенләй башка кешеләргә шалтыратып ята бит, ә!* Л.Ихсанова. *Кичә анасы тагын: «Баламны күрергә кайтам», – дип шалтыратып ята*. Р.Хәсәнова

**ШАЛТЫРА́У** *ф.* 1) Каты, гадәттә тимер әйберләр бер-берсенә бәрелгәләп, шалтыр-шолтыр иткән тавыш чыгару. *Һадины сискәндереп, капка келәсе шалтырады*. М.Хәсәнов. *Кызның кружкасына шалтырап акча коелды. Йөрәк өзгеч бу җыр барысының да күңелләрен тетрәткән иде ---*. М.Мәһдиев. *Ул, йозакны ачып, дугасын элмәктән алган булган икән инде, тимер бастырма кулыннан шалтырап җиргә төште һәм ишек ачылды*. Х.Камалов

2) Чайкалу, селкенү. *Тагы арбада шалтырарга, авыртудан телләрне чәйнәп, канатып бетерергә туры килде*. Х.Камалов. *Шунда товар ташучы поездның бер шалтыравык вагонына эләктем дә Урыссуга элдерттем. Шалтырап кайта-кайта йоклап кителгән*. Ф.Яруллин

3) Берәр прибор, җайланма тавыш сигналы бирү, чылтырау. *Без чыгарга җыенып кына беткәндә, телефон шалтырады*. М.Кәбиров. *Фәннур бер агарды, бер күгәрде, нәрсәдер әйтергә теләп, авызын ачты, әмма әйтергә өлгермәде – дәрескә чакырып, кыңгырау шалтырады*. А.Гыймадиев. *Ә берничә минуттан иртәнге алтыга куелган сәгать шалтыраячак иде*. Г.Нурулла

4) *күч.* Үтәдән-үтә кибү, корып кату. *Олег Антонов, кулына пычкы алып, шалтырап кипкән чыршыларны ваквак кыска пүләннәргә турап ташлады*. А.Хәсәнов. *Сбердлау урманнарыннан аякларына ырматиз эләктереп кайткан уллары Миңнетдин ---. Сөякләре кибә, ди, аның. Юкагач кебек шалтырап кибә, ди*. А.Хәлим

5) *күч.* Кирәккән-кирәкмәгән сүз, буш, мәгънәсез сүзләр сөйләп йөрү; мактану, шапырыну. *Хәл кылынып бетмәгән мәсьәлә турында шалтырап начар иткәнсез, иптәш Дубцова*. Ш.Камал. – *Главаның маңгаена пуля җибәргәннәр! – ди-ди шалтырап бара икән*. Ф.Баттал

◊ **Шалтырап тору** 1) Бөтенләй буш булу. *Пешерергә куймакчы идем, су беткән, чиләкләр шалтырап тора*. Н.Әхмәдиев. *Тагараклар шалтырап тора, маллар астында ник бер бөртек салам булсын*. Ә.Галиев. *Чүмеч белән чиләктән су алырга дип үрелде. Әмма ул буш, шалтырап тора иде*. Ф.Яхин; 2) Нык, үтәдән-үтә кипкән булу; 3) Нык ябык, арык булу, шыр сөяккә калу. *Минем каным белән туган илнең газиз туфрагы шулай күп сугарылган, күрәсең, шалтырап торган сөяктән һәм җыерчыкланып беткән тиредән башка бернәрсәм дә калмаган*. М.Яһудин

**Шалтырап алу** Бераз гына шалтырау. *Шул төннән башлап, ул йокыдан калды, ишек шыгырдаса да, капкакойма шалтырап алса да, өй почмагыннан мәче үрмәләп менеп китсә дә Нургали кайткандыр кебек тоела: – Син, син, карале, дим, ишетәсеңме?* М.Мәһдиев

**Шалтырап йөрү** Теләсә кайда, гел шалтырау. *Бу кем тагын, дөньяга сыймастай булып шалтырап йөри?* Р.Ишморат

**Шалтырап калу** Берәр эш-хәрәкәт артыннан шалтырау. *Иңбашларына куелган өр-яңа, көнгә дә рәтләп күренмәгән кызыл читле ука эполетлар, уңнан сулга таба ука бау белән асылындырып тагылган көмеш саплы нәфис кылыч, күкрәк өстендә кадалган көмеш герб белән гаскәри бер нишан Искәндәрне хикәяләрдәге шаһзадәләр кыяфәтенә

*кертеп, аның һәрбер килешле, матур адымы саен шалтырап калган шпор тавышлары йөрәктә күптән сүнгән әллә нинди бер дәрт, гайрәт кылларын чирткәндәй хис иттерәләр иде.* К.Тинчурин

**Шалтырап китү** Кисәк шалтырау. *Гомумән, шундый кашыгаяк бик шалтырап киткән чакларны алмаганда, татарның ире дә, хатыны да гаиләдә ул-кыз җиткереп, төче коймагын ашап дигәндәй яши бирәләр.* Н.Исәнбәт. *Шул арада тышкы ишек шалтырап китте, идәнгә йозак төште. Дамир тиз генә бер почмакка сыенды.* И.Хуҗин

**Шалтырап кую** Көтмәгәндә шалтырау; бер мәртәбә, кыска гына шалтырау. *Шулвакыт телефон шалтырап куйды һәм телефончы капитанны аппарат янына чакырды: Мәскәү!* И.Хуҗин. *Якалары тузган зәңгәрсу курткасы бөгәрләнеп беткән; атлаган саен, биштәрендәге буш банка белән алюмин калак шалтырап куя; сандалие, овчарка сыман, телен чыгарган.* А.Зәки

**Шалтырап тору** Даими, өзлексез, әледән-әле яки хәзерге вакытта шалтырау. *Арнольд өйләнгәч, йортка тынычлык иңдереп, көн-төн шалтырап торган телефоннар тынды.* Г.Нурулла

**Шалтырый башлау** Шалтыраргa тотыну. *Хуш, аннан китеп бераз баргач, кашыклары шалтырый башлады.* К.Насыйри. *Дания фатир ишегеннән кереп, өстен дә салырга өлгермәде, телефон шалтырый башлады.* Г.Габидуллина

**ШАЛТЫРАШУ** *ф. урт. юн. к.* **шалтырау**. *Ул арада чиләк-табаклар, шалтырашып, урыннарыннан кубалар.* Ф.Яхин

**Шалтырашып алу** Бераз гына, берара яки бер мәртәбә шалтырашу. *Кулыннан каз боты төшеп китте, тәлинкә, чәнечке, кашыклар кузгалышып, шалтырашып алдылар.* Ф.Яхин

**Шалтырашып кую** Бер мәртәбә шалтырашу. *Анда әтәчләр кычкыргалый, бозаулар мөгердәшеп алгалый, чиләкләр шалтырашып куялар ---.* Ф.Яхин

**Шалтырашып тору** Гел шалтырашу, гомумән шалтырау үзлеге булу; хәзерге моментта шалтырашу

**ШАЛТЫ́Р ИТҮ** *ф.* Кисәк шалтырап китү. *Күп тә үтмәде, кухня ягында нидер шалтыр итеп коелып төште.* Ф.Яруллин

**ШАЛТЫРМА** *и. диал.* 1) *к.* **шакылдавык**. *Икенче почмакта борынгы киндер сугу станы, тарак шикелле кылычлар, иләк кысасы кебек тобырчалар, калдырчалар, шалтырмалар...* А.Тимергалин

2) *к.* **калтырча**. *Шалтырмага шүре киертү*

**ШАЛТЫ́Р-ШОЛТЫР** *иярт.* **1.** 1) Авыр, зур металл әйбергә бәргәләгәндә яки шундый әйберләр бер-берсенә бәрелгәндә чыккан төрле тондагы тавышларны белдерә. *Тукта, чү, безнең дә монда кинәт шалтыр-шолтыр гөрелте купты!* Э.Касыймов. *Колакларында – алка, кулында – кечкенә тукмак. Һәрбер хәрәкәтеннән шалтыр-шолтыр тавышлар чыга.* Н.Фәттах

2) Тигезле-тигезсез ритмда селкенү, калтырау, чайкалу рәвешен белдерә. *Чокырларда арба шалтыр-шолтыр селкенә, яралылар ах-ух киләләр, яраларын тоткан итәләр.* Х.Камалов. *--- яшь кенә проводница кыз да керергә кат-кат үтенеп карады, әмма Рушан тәки шалтыр-шолтыр бәргәләнеп-суккаланып бара торган тамбурда басып калды.* Р.Мирхәйдәров

**2.** *с. мәгъ.* 1) Шалтырый торган, шалтыравык. *Калтырча шикелле шалтыр-шолтыр булса да, трамвай үзенекен иткән – егет йокыга талган һәм үз туктальшын узып киткән иде.* Р.Кәрами

2) *күч.* Көйсез, моңсыз; көе матур, төзек булмаган. *Шалтыр-шолтыр музыкага алар идән уртасыннан әйләнгәләп киттеләр.* Н.Фәттах

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Шалтыраган тавышлар чыгарып. *Бераздан калтырча «Запорожец» тө́тен торбасын җирдән шалтыр-шолтыр өстерәтеп китеп барды.* М.Галиев. *Телеграф баганасы очраган саен туктала-туктала шалтыр-шолтыр барган поезд Уфа вокзалына икенче көнне иртән генә барып җитте.* Р.Мөхәммәдиев

2) Ашыгып, кабаланып, дөбер-шатыр. *Шофёр бүген шалтыр-шолтыр йөри, Командировкага ашыга.* М.Шабаев

**ШАЛТЫ́Р-ШОЛТЫР ИТҮ** *ф. к.* **шалтырау**. *Кинәт кенә шалтыр-шолтыр итеп идән такталары чайкалып китте, әйтерсең лә өйгә дию пәрие килеп бәрелде ---.* М.Әмирханов

**ШАЛТЫ́Р-ШОЛТЫР КИЛҮ** *ф. к.* **шалтыр-шалтыр итү**. *Авторотадан ике тәүлеккә түләп алган «полуторка»га төялдек тә, яртылаш буш кузовта шалтыр-шолтыр килеп, юлга кузгалдык.* Ә.Маликов. *Тимер чәйнек белән шалтыр-шолтыр килеп, җәт кенә кайнар суга барып килде Мирсәет.* Р.Мөхәммәдиев

**ШАЛФЕЙ** *и. лат. бот.* Иренчәчәкләләр семьялыгыннан эфирга бай, шәмәхә чәчәкле, хуш исле, күпьеллык дарулы үләнчел үсемлек; теш уты, елан тамыры. *Чәй сары мәтрүшкә, шалфей, акчәчәк, эт шомырты чәчәге кушып пешерелсә, тонусны, кәефне күтәрә ---.* Т.Әйди. *Быелның апрелендә Русиянең баш санитар табибы Геннадий Онищенко тәмәке катнашмасы составында шалфей, Гавай розасы һәм зәңгәрсу лотос үләннәре булган матдәләр сатуны тыйган карар кертте.* Л.Гобәйдуллина

**ШАЛФЕЙЛЫ** *с.* 1) Шалфей үскән, шалфей күп булган. *Бирегә кызык бер күренешкә тап буласың – кара ылыслы көньяк тайгасы катнаш урманнарга, ә урманнар кылганлы, шалфейлы далага, йомраннар сызгырган, байбаклар йөгергән, ала каргалар, бүздәкләр очкан далага әйләнә.* Г.Паушкин

2) Шалфей кушылган, шуны салып әзерләнгән. *Шалфейлы чәй*

**ШАЛЯ́Й-ВАЛЯЙ** *рәв. рус* 1) Эшсез, эшләмичә, вакытны бушка уздырып. *Беркайда да эшләми, укымый торган, шаляй-валяй йөрүче, араларында хулиганнары да булган яшүсмерләрне исәпкә алып, һәрберсен, тәрбияви эш алып бару өчен, район җитәкчеләренә беркетеп чыктым.* Т.Галиуллин

2) Аннан-моннан, эштер-өштер, жиренә җиткермичә, түбән дәрәҗәдә. *Дядя Митрий шаляй-валяй эшләгәнне яратмый ул.* Г.Әпсәләмов. *Җыеп алу өчен иң авыры – бәрәңге. Монда кул көче сорала. Шәһәрдән тегеләй-болай гына кайтып, шаляй-валяй гына эшләп йөрүчеләр дә мәсьәләне хәл итми.* М.Мәһдиев

**ШАМА** *и. кыт. диал.* Чәйне пешереп, эчеп бетергәннән соң кала торган чүбе. – *Бу заманда комсыз байлар Ярлыны читкә тибәрә. Хәтта хәлфәне алдыйлар, Чәй диеп шама җибәрә, – ди һәм садакага җибәргән шаманы байның үзенә тоттырып китә.* С.Кудаш. *Менә аның [әнинең] чәй кайнаткан чыбыклары... Менә шама түккән җире.* М.Фәйзи

**ШАМАКАЙ** *и. фар.* 1) *тар.* Борынгы халык уеннарында, комедияләрдә, балаган тамашаларында төрле киемнәргә киенеп, кыланып халыкны көлдерүче комик персонаж; паяц; татарларда шамакай уенын алып баручы кыз. *Шамакай булып киенү*

2) Циркта төрле мәзәкле номерлар башкаручы, тамашачыларны көлдерүче

артист; клоун. *Цирктагы шамакай кебек, төрле-төрле төсләргә буянган.* Н.Гыйматдинова. *Җырчыны алып керен киттеләр. Келәмгә түгәрәк гәүдәле шамакай чыгып басты.* К.Кәримов

3) *тар.* Патша сараенда, бай йортта һ.б.ш.да кызык кыланмышлары, мәзәкләре белән хуҗаның һәм кунакларның күңелен ачучы кеше; *русчасы:* **шут**. *Заркан (Зеркон) – гаҗәеп язмышлы, даны әллә кайларга таралган шамакай. Коточкыч ямьсез кыяфәтле гарип – аксак, борынсыз, бөкре кәрлә.* З.Хәким. *Беркатлылар исә өстенлек сөйгән кешеләрнең күңелен күтәрер өчен кирәк, патшалар янында йөргән шамакайлар кебек.* К.Кәримов

4) Мәзәкчән, уен-көлке сөючән, шук табигатьле кеше. *Шамакай да инде бу егет!*

5) Үзен тиешенчә җитди тота белмәгән, гел маймыллана торган, төпсез, җиңел холыклы кеше; авторитетсыз, килде-китте кеше. *Курчак кебек матур кызы нindидер бер шамакай белән бәйләнгән!* И.Юзеев. *Ниһаять, сөйкемле, гакыллы, тапкыр Юркам ярты ел эчендә тәмәке пыскытып, гитара чиртеп, коридор тузанын кагып йөрүче шамакайларның берсенә әйләнде дә калды.* А.Гыйләҗев

6) Икейөзле, ялагай кеше; марионетка. *Яңа фаҗига шунда ки, кичәге кызыл авызлы фиркалыларга алмашка бүген милләтпәрвәр булып кыланучы тәмле телле шамакайлар килде.* А.Тимергалин. *Банкет – хәерчеләр, ялагайлар һәм шамакайлар оҗмахы.* З.Хәким

**ШАМАКАЙЛАНУ** *ф.* 1) Шаярту, кешеләрнең күңелен күтәрергә, көлдерергә тырышу. *Ләкин ул анда да тик кенә тора белми, куллары белән нindидер фокуслар күрсәтә, шамакайлана.* Х.Камалов. *Сезнең күңелне күрер өчен генә шамакайланасым килми.* К.Кәримов

2) *күч.* Үзен тиешенчә җитди тотмау, сүзне урынлы-урынсыз көлкегә бору, маймыллану. *Әдәби материалда уенны арзанлы көлдерүгә, шамакайлануга борып җибәрү өчен мөмкинлекләр җитәрлек.* А.Әхмәдуллин. *Җиңел-җитез адымнар белән рәтләр буйлап китте, кемгәдер елмаеп сүз катты, кемнәргәдер назлы-җылы комплиментлар әйтте, шаярды, көлде, бу дөньяда бер генә гаме, бер хәсрәт-мәшәкате юк кеше сыман рәхәтләнеп шамакайланды.* Р.Мулланурова

**Шамакайлана башлау** Шамакайланырга тотыну. *– Вакыт бездә капчыгы белән, – яңадан шамакайлана башлады егет.* Р.Гаязетдин

**Шамакайланып алу** Бераз вакыт, берара гына шамакайлану. *Картның әллә нигә шамакайланып аласы килеп китте.* Р.Гаязетдин

**Шамакайланып йөрү** Озак вакыт, еш кына шамакайлану. *Камил Мотыйгыйның үзен үзе «татар Шаляпины» дип атап шапырынуы, Тукай белән араларының киселүе, 1915 елда, мөфти Солтанов вафат булганнан соң, үз кандидатурасын мөфтилеккә тәкъдим итеп шамакайланып йөрүе кебек тискәре фактлар да Сүзлектә ачылмаган, ягъни Мотыйгыйның фаҗигалы тормышы берьяклы гына яктыртылган.* А.Тимергалин. *Фәгыйльне баштанаяк җентекләп күздән кичерде дә өнәмәвен яшермичә мыгырдап куйды: – Мөслимә башың белән шамакайланып йөрмә монда, бар, юлыңда бул, китә бир.* С.Сабиров

**Шамакайланып тору** Күпмедер вакыт шамакайлану; хәзерге моментта шамакайлану. *Минем ахмагым, беләсең килсә, шамакайланып торма әле, Нурсөя.* М.Хәбибуллин. *Ә сез, биюче булгач, ул клоун сыман гел көлеп, шаярып, шамакайланып торырга тиештер, дип уйлагансыздыр, шулаймы?* З.Хәким

**Шамакайланып утыру** *сөйл. к.* **шамакайланып тору**. *Әлбәттә инде, җитди эш вакытында шамакайланып утырган Гомәр укытучының ачуын китерә.* Г.Рәхим

**ШАМАКАЙЛЫК** *и.* 1) Клоунлык, шамакай (*1–3 мәгъ.*) шөгыле һәм осталыгы. *Халык, ди ул [Ш.Әхмәдиев], театрга, концертка тәрбия, әхлак алу, күңел ачу өчен бара. Ләкин һич тә шамакайлыкны, балаган уенын карар өчен түгел!* М.Мәһдиев. *Актёрларның уеннары да шамакайлыкка күбрәк корылган булырга тиеш.* Р.Батулла

2) *күч.* Шамакай (4–6 мәгъ.) холкы, җиңел акыллылык, җилбәзәклек; җитди булмаган, мәгънәсез кыланыш. *Ул яшьтән үк ахмаклыкны, шамакайлыкны гына түгел, артык беркатлылыкны да яратмады.* Д.Каюмова. *[Асук:] Без шул ахмак шамакайлыктан качып, дөнья малыннан ваз кичеп, вак мәшәкатьләрне ташлап, дәрвиш булып киттек ич инде.* Р.Зәйдулла

**ШАМАКА́Й УЕНЫ** *и.* 1) *этн.* Яшьләрнең кичәләрендә җен булып киенгән кызның башкаларны аздыру өчен вәсвәсәләр сөйләвеннән гыйбарәт драматик күренеш. *Драматик (ягъни диалоглы, кара-каршы әйтешә торган) әсәрләр булса да, алар халыкта күбрәге шамакай уеннары, «Алырмын кош – бирермен кош», «Күктә, күктә ниләр бар?» уеннарында әйтелә торган сүзләр шикелле генә нәрсәләрдер.* Г.Газиз. *Аулак өйдәге иң кызыклы уен – шамакай уенын Сәҗидә башлап җибәрде.* М.Галәү

2) Кирәкмәгән эш-гамәл, килешмәгән кыланыш

**ШАМАН** *и. эвенк.* Шаманистик, мәҗүси ышанулар буенча, транс халәтенә кереп рухлар белән аралаша, шулар ярдәмендә авыруларны дәвалый, күрәзәлек итә дип күзалланган дин әһеле; кам. *Безнең максат – халыкны шаманнардан, төрле еретиклардан арындыру һәм изге дингә тарту...* М.Хәбибуллин. *Сине – христиан диненә йөз тоткан императорны – камнар, шаманнар кызыксындырмагач, хәбәр итеп тормадым.* З.Хәким

2) *к.* **шаманизм**. *Шаман йолаларында даими кулланыла торган шөлдерле барабанның иң әһәмиятле детале – тоткасы каен агачыннан ясалган.* Ф.Урманче

3) *күч.* Күз буяучы, махинация остасы. *Казан шаманнары федераль салымнарны азрак түләп, милли кесәләрен калынайткан нефтедолларлар хисабына ачәрвахлар үрчетеп яталар, имеш.* А.Тимергалин

**ШАМАНИЗМ** *и. эвенк.+гр.* Шаманның транс («камлау») халәтендә рухлар белән элемтәгә керә алу мөмкинлегенә ышануга таянган, магия, анимизм, фетишизм һәм тотемизм белән бәйле диннең башлангыч формасы. *Ләкин казакълар чын мөселманнар түгел, шаманизм дине аларның тормышында гореф-гадәт төсен алганга, казакъның дин белән артык эше юк.* Г.Ибраһимов. *Чувашларның дини инануларында галимнәр зороастризм һәм шаманизм элементларын табалар; шулай ук ислам дине дә чувашларның дини карашларында яңа культлар барлыкка килүгә этәргән.* Б.Хәмидуллин

**ШАМАНИ́СТИК** *с.* Асылы шаманизм булган, шаманизмнан гыйбарәт, шаманизм белән бәйле. *Шаманистик күзаллаулар төрки кабиләләр алдында туган тормыш мәсьәләләренә бер яктан да җавап бирмиләр – алар инде искерген булалар.* Р.Әхмәтьянов

**ШАМАНЛЫК** *и.* 1) *к.* **шаманизм**. *Шулай итеп, ул регионнардагы төрки халыклар меңнәрчә еллар элек шаман-*

*лыкта булганнар, аннары тәңречелек дине тотканнар (һуннар, төркиләр) ---.* И.Хуҗин. *Безнең Гәрәй һәрнәрсәдән шаман инструментлары эзли. – Диплом темасы шаманлык булгач.* М.Госманов

2) Шаман булу. *Шаманлык һөнәрендә иң мөһиме – табигатьтәге хайван, агымсу, җил-давыл авазларына имитация ясау була (төрки телләрдә тәкълиди сүзләрнең байлыгы шуннан килсә кирәк) ---.* Р.Әхмәтьянов. *Якут олонхоларының уңай персонажлары, Алтай эпосы каһарманнары, безнең мәшһүр Идегәй кебек батырларда сихер көче, магия, тылсым, шаманлык, кансызлык, чиктән ашкан кирелек, үзсүзлелек, мактанчыклык кебек сыйфатларның барысы да бар.* Ф.Урманче

**ШАМАННА́РЧА** *рәв.* Шаманнар кебек, шаманнар рәвешле. *Майяның чын шаманнарча камлавын язучы бик матур һәм ышандырырлык итеп сурәтли.* Ф.Урманче. *Дөрес, ул шаманнарча ут-ялкын тирәсендә сикерепукынып йөрүчеләрдән түгел.* К.Җәмит

**ШАМАНЧЫ** *и.* Шаманизм динен тотучы, шаманга ышанган кеше. *Режиссёр Андрей Борисов, якутларның Олонхо халык авыз иҗаты төрен һәм шаманчылар традицияләрен берләштереп, шуларга җыр традицияләрен дә кушып, үзенә бертөрле театр барлыкка китерә.* Мәдәни җомга

**ШАМАНЧЫЛЫК** *и. к.* **шаманизм**. *Татарларда җилән руханилар киеме булып исәпләнгән һәм бу, күрәсең, борынгы шаманчылыктан ук килә.* Р.Әхмәтьянов

**ШАМБЫ** *и. фин-угор зоол.* Тәрәчсыманнар отрядыннан төче суларда тереклек итә торган ерткыч балык; жумба; *русчасы:* **налим**. *Көмештәй ялтырап торган чабагын да, юантык кызылканатын да, сап-сары, чабатадай киң корбанын да, кап-кара, шома сыртлы шамбысын да, тыгыз һәм симез тәнле бәртәсен дә, буй-буй майкалы алабугасын да, ертлач оптысын да аз каптырмадылар алар.* М.Хәсәнов

**ШАМОТ** *и. фр. тех.* **1.** 1) Югары температурада яндырылып, утка чыдам хәлгә китерелгән кызыл балчык яки каолин. *Сынчы күбрәк балчыкның бик йомшак һәм җылы шамот дигән төрен кулланырга ярата.* Л.Әсәдуллина

2) Шундый ысул белән ясалган кирпеч, плитка һ.б.ш. нәрсә. *Шамот заводы прокат корпуслары, тагын ниләр генә юк иде анда!* Казан утлары

**2.** *с. мәгъ.* Шундый ысул белән ясалган, утка чыдамлы. *Шамот кирпеч*

**ШАМПАН** *и.* Франциянең Шампань провинциясе исеме белән аталган, икенче тапкыр ачыту юлы белән углекислый газга туендырылган, чемердәп тора торган йөзем шәрабы. *Якыная төшкәч күрәм: иң түр почмактагы кечерәк кенә өстәл янында өч кыз утыра. Алларында ике шампан шешәсе, аның берсе инде бушаган.* М.Вәли-Барҗылы

**ШАМПАНЛАШТЫРУ** *ф.* Шәрабны икенче тапкыр әчетү юлы белән углекислый газга туендыру

**ШАМПА́НСКИЙ** *и. рус к.* **шампан**. *Казанга кайтып, шампанский эчәрмен дип уема да китермәгән идем.* Ә.Еники. *Тик Фәләх кенә, җаваплы кеше – бүлмә хуҗасы буларак һәм гомумән эчүгә шаккатмаганлыктан, беренче тостган соң азрак шампанский эчеп куйды да мәҗлес таралганчы тамчы да капмады.* В.Нуруллин

**ШАМПАНЧЫ** *и.* Шампан шәраблары белгече; *русчасы:* **шампанист**

**ШАМПИНЬОН** *и. фр.* Шампиньончалар семьялыгыннан ак төстәге калын эшләпәле ашарга яраклы гөмбә. *[Җанбатыр:] Чыгарып сал инде макталган шампиньон пирогын!* Р.Гаязетдин

**ШАМПИНЬО́НЧАЛАР** *и. күпл. бот.* Шампиньон, ку гөмбә һ.б. киң таралган ашарга яраклы һәм агулы гөмбә төрләрен эченә алган семьялык

**ШАМПИНЬОНЧЫ** *и.* Шампиньон гөмбәсен җитештерү белгече; *русчасы:* **шампиньоновед**

**ШАМПУНЬ** *и. ингл.* 1) Чәч юу өчен кулланыла торган, сыекча, крем яки порошок хәлендәге хуш исле матдә. *Сиңа нинди шампунь кирәк, Фирая, майлы чәч өченме, әллә кавыклы чәч өченме?* Л.Лерон. *Чәчләрне шампунь белән юганнан соң кондиционер куллану да мөһим.* Матур буласың килсә

2) Хайваннарны яки техниканы юу өчен кулланыла торган, гадәттә сыек хәлдәге махсус кушылма. *Сезнең халык, эт малае диеп уйламассың. Үзеннән хушбуй исе килеп тора.* Затлы шампунь белән юганнар. Д.Салихов. *Тобикның йонын матурлап кыркалар, затлы шампунь белән юалар. Бу эшкә Галочкин илле сум түли.* М.Юныс

3) Гомумән хуҗалыкта юу, чистарту, тап чыгару, ялтырату кебек төрле максатларда кулланыла торган сыек көндәлек химия чарасы. *Ак, кызыл, кара мәрмәр җәйгән киң проспектларны шампунь белән юа торган техника кайтартканнар.* Ф.Баттал

**ШАН** *и. гар. кит.* 1) *к.* **дан** (*1 мәгъ.*). *Иптәш Исхаков хезмәт иткән полк байрагы кышкы һөҗүм сугышлары вакытында яңа дан, яңа шан белән бизәлә.* Г.Кутуй. *Дан килер, Шан килер – Илеңдә күкрәрсең!..* Л.Зөлкарнәй

2) Дәрәҗә, мәртәбә, престиж, игътибар, абруй, шөһрәт. *Бу уникe агай-эне... Биктимер бабайның шанын, шәрәфен саклап, шуның аркасында үзләре дә рәхәт-рәхәт яшәп килделәр.* К.Тинчурин

**ШАНКР** *и. фр. мед.* Йогышлы авыру китереп чыгара торган микроорганизм тәнгә үтеп кергән җирдә барлыкка килгән эренле куык, соңрак – уелып торган җәрәхәт. *Шанкрның зурлыгы энә очыннан башлап 2 см һәм аннан да зуррак булырга мөмкин.* Минем йорт

**ШАНЛЫ** *с. кит. к.* **данлы**. *Кояш астында үз урыныңны алып, җирдә ышанычлы нык басып яши алу, шуңа өстәп зур хезмәтләр һәм шанлы исем калдыру, һай, җиңел түгел бу дөньяда!* Р.Фәйзуллин. *Янгын давыллары Казан өстендә байтак булды, булачаклары хәтәррәк, ә без күргәннәр, сез күрәчәкләрне оныклар, торыннар каян белер? Данлы, шанлы тарихыбыз янып бетәчәк.* Р.Батулла

**ШАНС** *и. фр.* Берәр эш-хәлнең үтәлүе, өмет-теләкнең тормышка ашуы өчен барлыкка килгән уңай момент, шуның өчен кирәкле шарт, форсат, мөмкинлек. *Булырмы ул, тарих безгә шанс, өмет бирерме?* Н.Шәрифуллин. *Бу – гомергә бер була торган шанс. Кулдан ычкындырсак, без – ахмак, дурак, дундук! Соңыннан гомер буе үкенәчәкбез.* Н.Гаетбай

**ШАНСОН** *и. фр.* 1) Берничә тавышка башкарылган борынгы француз җыры

2) Шансонье репертуарындагы халык яки заманча эстрада җыры, XX гасыр француз эстрадасының популяр жанры

3) Заманча музыканың төрле жанрларын, башлыча халыкчан, гади көйле һәм эчтәлекле җырларны берләштергән җыйма термин. *Башка җырлар ниндирәк рухта, барысы да шансон стилендәме? Яшьләргә юнәлгәне бармы?* Р.Исхакый. *Татар җыры соңгы вакытта бик нык чуарланды, шансон, попса һәм рэп җырлаучылар барлыкка килде.* Кәеф ничек?

**ШАНСОНЕТ** *и. сөйл. к.* **шансонетка** *(1 мәгъ.). Заманында Рәсәйдә дистәләгән байбичәләр сөяркәсе булып*

*типтереп йөргән Александр Вертинский атлы бик данлыклы җырчы хәзер монда кич саен тамак ялына, исерек көенә шансонетлар суза.* В.Имамов

**ШАНСОНЕ́ТКА** *и. фр.* 1) Кафешантаннарда җырлана торган җиңел, кайвакытта әдәпсезрәк эчтәлекле эстрада җыры

2) Шундый җырлар башкаручы хатын-кыз, кафешантан җырчысы. *«Болгар», «Амур», «Сарай» номерларында татар рестораннары, татар музыкантлары, татар җырчылары (дөресрәге, шансонеткалары).* Ә.Еники. *Ильич, эшче кварталларда бөтен нәрсә турында – исерек крестьяннарның депутатлар палатасына узгынчы бер агитаторны сайлаулары турында, балалар тәрбияләү турында, эшсезлек һ.б. турында җырлаучы революцион шансонеткаларны тыңлау өчен, төрле кафеларга һәм шәһәр чите театрларына бик теләп йөри иде.* Казан утлары

**ШАНСОНЬЕ** *и. фр.* Гадәттә үз җырларын башкарган француз эстрада җырчысы; гомумән автор-башкаручы. *Җир яшьлеген балкып җырлады ул, кушылды аңа Кояш – шансонье!.. Җир утлары кушыла аңа янып, дөрләп кушыла кояш факеллары.* Роб. Әхмәтҗан. *Шушындый ук йортта, әле биредән ерак та түгел бугай, чыгышы белән әрмән булган бөек француз җырчысы шансонье Шарль Азнавур тора иде.* Р.Мирхәйдәров

**ШАНТАЖ** *и. фр.* Шантажлау гамәле, шуннан гыйбарәт җинаять. *Моннан алда әллә ничә тапкыр сөйләшеп, Акимовның шантаж юлы белән бу һөҗүмнән качарга ниятләгәнен белделәр.* Х.Камалов. *Аның инде шулай шантаж белән акча эшләүчеләр хакында ишеткәне бар иде.* И.Сираҗи

**ШАНТАЖЛА́У** *ф.* Берәүнең серен, гаебен, җинаятен белеп, шуны фаш итү белән янап, аннан акча яки берәр башка нәрсә таләп итү, берәр үзенә файдалы эш-гамәлгә мәҗбүр итү. *Син мине шантажлый алмассың, кабахәт!* Р.Батулла

**Шантажлап алу** Аз гына шантажлау. *Мин дә, сүзне уенга борып: «Ә мин син әйткәннәрне Мәдинә апа белән Хаммат абыйга (сугыштан соң туган балаларның исәннәре) «шакыйм», – дип «шантажлап» алдым.* Татарстан яшьләре

**Шантажлап тору** Даимән, гел шантажлау; хәзер, әле шантажлау

**Шантажлый башлау** Шантажларга тотыну. *Һәм мәкерле Дәрвиш, шушы хәлдән файдаланып, Тәңкәбикәне шантажлый башлый.* Р.Батулла

**ШАНТАЖЧЫ** *с.* Шантаж белән шөгыльләнүче кеше. *Мөгаен, ул шушының белән шантажчыларның карталарын бераз гына булса да бутады.* Ә.Баян. *– Димәк, син – гади шантажчы, – диде бераз тынычлана төшкән һәм аналитик акылын эшкә җигәргә өлгергән Майкл.* И.Хуҗин

**ШАНТАН** *и. фр. к.* **кафешантан**. *[Обывательнең] сәхнәдә кәефне бозмый торган, тук тәненә ял бирә торган яки аның хайван хисләрен кытыкландыра торган нәрсәләр генә күрәсе килә. Шуның өчен Европада драманың һәлакәте нигезендә ялангач хатыннар бии торган шантаннар, салоннар үсә.* Һ.Такташ

**ШАНТРАПА** *и. фр. сөйл.* **1.** 1) Халык арасында авторитеты булмаган, абруйсыз, әһәмиятсез, юньсез, начар кеше. *Рафил Зәйнуллин спектакльдә ике роль – һәрьяклап уңай герой Фәнилне һәм порнуха ясатучы шантрапа, эретеп ябыштыручы Илмир ролен башкарды.* Сәхнә

2) Теләсә нинди юньсез кешеләр, этрәк-әләм. *Икебез ике марҗа кызын әләктереп китеп барганда, әллә каян бер көтү шантрапа килеп чыгып безгә ташланмасынмы?* Ф.Яруллин. *Чөнки шулкадәр әшәке система төзелгән – җыен шантрапа хакимият башында утыра.* З.Зәйнуллин

**2.** *с. мәгъ.* Абруйсыз, әһәмиятсез, юк-бар, ни җитте шундый, килде-китте (кешеләр тур.). *Җыен шантрапа халык килеп тулгач, яхшы фатир да булмый.* Т.Гыйззәт

**ШАҢ** I *и. тар.* Тоташ тимердән чүкеп ясалган сугыш киеме, панцирь. *Хан сарайга килгәндә, Хан сарайның ишеген Каһәр белән ачып кергәндә, Тимердән суккан шаң киеп, Вәзирләр белән куршанып, Түрдә утырган Кыйгырчык – Аны күрде Идегәй.* Дастан

**ШАҢ** II *иярт.* 1) Берәр яңгыравык каты өслеккә бәргәндә чыга торган тавышны белдерә

2) *к.* **шап**. *Эчен ачып карарга азапланганда, шаң моның ике каш арасына бар булган куәт белән.* Ф.Дәүләтбаев

**ШАҢГЫР** *иярт.* **1.** Тимер тимергә бәрелгәндә чыккан саңгырау, тонык чыңлау тавышын белдерә. *Чиләк шаңгыр итеп тимер кисәгенә бәрелде*

**2.** *и. мәгъ.* Шундый тавыш. *Шаңгыр яратмаган кеше тимерче алачыгына кермәс.* Мәкаль

**ШАҢГЫРАВЫК** *и. диал.* **1.** Кыңгырау. *Кич булганда, чыңгылдавыклар бәйләгән, шаңгыравыклар таккан икешәр, өчәр атлы --- арбалар кайтырга чыга.* Шура

**2.** *с. мәгъ.* 1) Чыңлый торган, яңгыравык. *Шаңгыравык тавышлы хатын*

2) Шалтыравык; мактанып, шапырынып әйтелгән. *Бу шаңгыравык сүзләр авыр хәлне каплап торыр өчен кирәк микән?* Ш.Маннур

**ШАҢГЫРАК** *и. к.* **чаңгырак**. *--- «дала буйлап йөрүче ул җенле җегетләр гел дә барымтачылар түгел икән, алар мохтаҗларга ярдәм итеп, йортсызга йортлык киез, шаңгырак, киерге ташлап китә --- икән» дигән хәбәрләр дә таралды.* Р.Батулла. *Яу кирәк-яракларын, чатыр киезен, шаңгыракларны, киергеләрне өченче атка төягәннәр.* Безнең мирас

**ШАҢГЫРА́У** *ф.* 1) Тонык кына калын тавыш белән яңгырау. *Карчыга, канат ачып, һава йөзенә чыкты һәм --- очып йөргәндә күрде: бер кыр бүдәнәсе дигән көяз кош төрле көй вә наз белән ары-бире әйләнеп йөреп очадыр вә шаңгырап көлүе белән тау-ташны яңгыратадыр.* Әкият. *Күк ярылып чатырдый, тау шаңгырый ---.* Дәрдемәнд

2) Кайтавазланып яңгырау; гөжләү. *Карт, мәһабәт ямь-яшел урман музыканың һәм кошларның төрле ноталары белән бер яңгырады, бер шаңгырады, бер моңлы гына ыңгырашты, бер шат кына көлеп тагы яңгырады, тагы шаңгырады.* Ф.Әмирхан

3) *күч. диал. к.* **шаңку** (*1 мәгъ*). *Ире килеп җиткәндә, хатын җансыз иде инде. --- Яшь врач тәмам шаңгырап, нишләргә белми утырганда, баш табиб Риф Фәритович үзе килеп керде.* З.Мурсиев

**Шаңгырап алу** Берникадәр вакыт шаңгырау

**Шаңгырап калу** Кинәт, берәр көтелмәгән хәлдән шаңгырау. *Ходай кодрәте белән адәм баласының табигате шулай корылган – ул чиксез бәла, кайгы килгәндә шаңгырап кала, ягъни афәтнең шулкадәр дә зур --- икәнен шундук аңлап бетерми.* З.Мурсиев

**Шаңгырап кую** Кинәт, көтмәгәндә, бер тапкыр шаңгырау. *Яшен суккан агач сыкрап шаңгырап куйды*

**Шаңгырап тору** Әле, хәзер, сөйләү моментында шаңгырау

**Шаңгырый башлау** Шаңгырарга тотыну

**ШАҢГЫРДАТУ** *ф. йөкл. юн. к.* **шаңгырау**. *Шаңгырдатып мич авызын ачты, шунда гына йорт эченә бераз яктылык төшеп, анда-монда нәрсәләр барлыгын ачыграк чамаларга мөмкин була башлады.* Ф.Яхин

**ШАҢГЫРДАТЫП** *рәв. к.* **шартлатып**. *Һәр сораганда, күп сүз белән киңәйтеп, шаңгырдатып җавап бирде.* Г.Ибраһимов

**ШАҢГЫРДА́У** *ф. к.* **шаңгырау**. *Шаңгырдап чыккан шул агач көе ничек шулай бөтен авылны дулкынландыра ала икән?* Г.Бәширов. *Кинәт өйнең иске бишмәт чабуы кебек җилдә җиңеләйгән, калтайган ишеген эчтән этәреп җибәрделәр, ишек шаңгырдап ачылды ---.* А.Хәлим

◊ **Шаңгырдап торган** Бернинди кимчелеге булмаган, нык, сыйфатлы, яңа (йорт, бүрәнә, бура тур.). *Төп нигез таштан корылды. Кып-кызыл, янган кирпечтән ---. Икенче йорт шаңгырдап торган нараттан салынды.* Р.Батулла

**Шаңгырдап алу** *к.* **шаңгырап алу**. *Төнге салкында каткан өйалды сайгаклары шаңгырдап ала, һәм, баскычны шыгырдатып, берәү безнең янга төшеп килә.* М.Мәһдиев

**Шаңгырдап кую** *к.* **шаңгырап кую**

**Шаңгырдап тору** *к.* **шаңгырап тору**. *Пөхтә итеп җәелгән паласлар өстендә ап-ак йон оекбашлары белән тигез рәтләргә басып, шаңгырдап торган көчле тавыш белән тәравих зикерен әйткән безнең ак бабайларыбыз һәм авыл аксакаллары әле дә күз алдында ---.* Безнең гәҗит

**Шаңгырдый башлау** *к.* **шаңгырый башлау**

**ША́ҢГЫР-ШОҢГЫР** *иярт. к.* **шалтыр-шолтыр**. *Шау-шу кубарып, немецларның игътибарын вакытыннан элек җәлеп итмәс өчен, һәрвакыт шаңгыр-шоңгыр тәгәрәтеп йөртә торган тимер кыршауларын өйдә калдырдылар.* Ф.Яруллин. *Бу вакытта тимер арбаның тәгәрмәчләре, шаңгыр-шоңгыр өзек тавышлар чыгарып, артта куе тузан болыты сузып калдыра.* С.Поварисов

**ШАҢДА́У** *и.* Яңгыравык, кайтаваз. *Адаштырып йөрәк авазымны, ишетерә шаңдау: «Ул яман!..»* З.Мансуров. *Җир тетрәтеп чапкан корыч айгыр, юл буендагы яшь каеннарны сискәндереп, дөньяга гайрәтле аваз салганда, синең иркенлегең, азат ил баласы булуың искә төшә; шаңдау, урманнарга бәрелеп, кире кайта: – Ааа-ааа...* Г.Ахунов. *Шаңдау булып кайтавазлар килә Даукөрәшле кайнар көннәрдән.* Р.Низами

**ШАҢК** *иярт.* Берәр яңгыравык каты өслеккә кисәк бәргәндә чыккан өзелеп калган тавышны белдерә

**ШАҢКАЮ** *ф.* 1) Туңу, шакыраеп кату, бөгелмәс, сыгылмас хәлгә килү; катып калу. *Чөнки солдат кыш буенча гүрокопта шаңкаеп, Мәрхәмәтсез кышкы салкынны татый хәлдән таеп.* Г.Сөнгати

2) *к.* **шаңку** (*1 мәгъ.*)

**Шаңкаеп калу** Нииндидер тәэсирдән соң шаңкаю. *Гимран Гимаевич, борылып, капкадан кереп китә. Барысы да шаңкаеп калалар.* З.Хәким

**Шаңкаеп тору** Әле, хәзер шаңкайган хәлдә булу. *[Әвеш (диванга лаҗыраеп)]: Мин пилорам директоры. [Вәяз (беравык шаңкаеп торып)]: Әвеш Тәвешевичмы әллә?* З.Хәким

**Шаңкая башлау** Шаңкаюга таба бару

**ШАҢКУ** *ф. сир.* 1) Бәрү, сугу. *[Кыяр башлының] аягыннан эләктереп алдым да торып бастым, болгап, монысының башы белән тегесенең башына шаңкыдым. Беразга икесе дә исәңгерәп киттеләр.* Ф.Баттал

2) *күч.* Миңгерәүләнү, аңгыралану, билгеле бер вакытка аңлау сәләтен югалту

**Шаңкып йөрү** Күптәннән бирле, шактый вакыт шаңкыган хәлдә булу. *Егет --- бернichә ел шаңкып йөргәннән соң, сарт юлына төшеп, көн чыгышына карап китеп барды.* З.Мурсиев

**Шаңкып калу** Нииндидер тәэсирдән соң шаңку. *Шуннан соң военком Сапожников, МТС директоры --- чыгыш ясадылар. Без ул чакта шаңкып калган идек, кемнең ни әйткәнен дә хәтерләрлек түгел.* З.Мурсиев

**Шаңкып китү** Кинәт шаңку. *Якында гына аллы-артлы ике мина шартлады. Кәримнең башы шаңкып китте.* Ә.Хәкимов

**Шаңкып тору** Сөйләү моментында шаңкыган булу; вакытлыча шаңку

**ША́ҢК-ШОҢК** *иярт.* Кечерәк әйбер зур каты өслеккә бәрелгәндә чыккан яңгыравык өзек-өзек тавышны белдерә. *Карт кинәт урыныннан сикереп торды да, тимер таягын шаңк-шоңк китереп, су буйлап китте.* Ф.Җамалетдинова

**ШАҢРА́У** *ф. к.* **шаңгырау**. *Агач, таш эчләре шаңрап, Киләдер бер нида яңрап.* Дәрдемәнд

**ША́Ң-ШАҢ** *иярт.* 1) Матур, яңгыравыклы, көйле итеп сөйләшү яки җырлау тавышын белдерә. *Ул, шаң-шаң итеп, авыл өстенә саф тавышлы яшь егет җырыдай шатланып күтәрелә.* Г.Бәширов

2) Калайга калай бәрелү һ.б.ш.дан чыккан ямьсез, кискен яңгыравык тавышны белдерә

**ША́Ң-ШОҢ** *иярт.* Төрлесе төрле югарылыкта чыккан яңгыравык тавышларны белдерә. *Әллә козгыннар, әллә безнең күрше Халисә апа шаң-шоң сөйләшәме?* Р.Газизов

**ШАП** *иярт.* **1.** 1) Каты өслеккә берәр нәрсә килеп төшкәндә, бәрелгәндә, яссы нәрсә белән сукканда, ике яссы әйберне бер-берсенә бәргәндә барлыкка килгән саңгырау тавышны белдерә. *Тал балалары, балакларын сызганып, кызыл балчыкка салам кушып, изелмә, изелмәгә, хуш исләре аңкып торсын өчен, канәфер орлыклары өстәделәр, аны изделәр һәм, шап та шоп китереп, саман кирпечләре суктылар.* А.Хәлим

2) Берәр эш-гамәлнең кисәк, бик тиз, бер хәрәкәттә башкарылу рәвешен белдерә. *Моны ул үзе дә чамалады, гадәтенчә шап туктады да бер сүз дә әйтмичә китеп тә барды.* Л.Ихсанова. *Шунда Гайфи көлеп утырган җиреннән туктап, шап итеп авызын япты.* Аманулла

**2.** *хәб. мәгъ.* Кисәк китереп сугу, бәрү, бәрелү турында. *Тегесе дә җитез – шап маңгаена.* С.Шәрипов. *Уйга бирелеп, искәрмичәрәк калган икән, маңгае белән шап бетонга!* Н.Әхмәдиев

**ШАПА** *с. диал.* 1) Артык зур авызлы (кеше тур.)

2) Чамасыз сүзчән, сөйләмчәк

3) Авызында сүз тормый торган, сертотмас

**ШАПАЙ** *с. диал. к.* **шапа**. *Туктыйсыңмы син миңа бәйләнүдән, шапай авыз.* Т.Миңнуллин

**ШАПАЛАК** *и. сөйл.* **1.** 1) Чебен, озынборын кебекләрне үтерү өчен башында яссы, киңәебрәк торган өлеше булган җиңел әсбап; чебенүтергеч. *Шапалакка кунган чебен исән кала...* Ш.Галиев. *Тәрәзәләрне томалап, ишеккә кусаң, чыгып качалар. Калганнарына менә шапалак.* Ә.Хәсәнов

2) Кисәк, шап итеп, кулны йодрыкламыйча, уч белән сугу рәвеше; яңаклау. *Акыру гына түгел, сезгә шапалак төшерәсе иде дә, кешесе юк.* Т.Гыйззәт

3) *к.* **шапылдавык** (*3 мәгъ.*). *Шапалак дигәне – бер-берсенә беркетелгән ике шома агач кисәге. Йонны шулар*

*арасына кыстырып, үтүкләгән кебек эшләүне «шапалату» ди икән каргалылар*. Безнең гәҗит

**2.** *с. мәгъ.* 1) Ашыгып сөйләве яки сакаулыгы аркасында сүзе аңлашылмый торган. *Шапалак малайларның күбесенә хас булганча, биш яшькә чаклы җөнле-рәтле теле ачылмады.* Г.Ахунов

2) Шапшак (*1 мәгъ.*), шакшы, җыйнаксыз. *Сәйрүз – шапалак, рамнарны гына түгел, тәрәзә пыялаларын да «буяп» чыккан.* Шәһри Казан

**ШАПАЛАНУ** *ф. диал.* Артык дулкынлану, борчылу, чәүчәләкләнү. *Имеш, шапалану аркасында сәламәтлеккә күбрәк зыян салабыз. Әмма паникага бирелү битарафлыкка караганда кулайрактыр.* Л.Закиров

**ШАПАЛАТУ** *ф. диал.* Мамык, йон һ.б.ш.ны махсус әсбап – шапалак ярдәмендә язу, күпертү. *«Беренче эш итеп, дебетне язабыз. --- Шуннан соң берничә тапкыр шапалак белән шапалатабыз», – дип сөйли Гөлниса апа.* Безнең гәҗит

**ШАПА́Н-ШОПАН** *иярт. к.* **шыпан-шыпан**. *Ике исерек, шапан-шопан ашыгып, мыштым гына сызу ягын карадылар.* Ф.Яхин

**ША́П ИТҮ** *ф.* Бер мәртәбә кисәк бәрелү, төшү һ.б.ш.дан шапылдаган тавыш чыгу. *Суккалый торгач, ахырда чөй чыгып, бушап китеп, Шүрәленең бармагы калды кысылды шап итеп.* Г.Тукай. *Нәрсәдер шап итеп идәнгә төшкән тавышка күзләрен ачты.* Х.Камалов. *Кайтырга дип кузгалыйм гына дигәндә, якындагы куакта нәрсәдер шап итте дә, куак дер селкенә башлады.* Н.Каштанов

**ША́ПКА** *и. лат.* 1) Күрек, мамык һ.б.ш. материалдан эшләнгән җылы баш киеме. *Фотоларда каракүл шапка кигән хатын-кызлар, ирләр балык тота.* А.Кормаш // Гомумән төрле җылылыкта, төрле материалдан һәм төрле фасонда эшләнгән баш киеме. *– Әйтмичә калсам, йокым йокы булмас, сиңа бу шапкаң бик килешә, Маһирә, – дидем ---.* Ф.Хөсни. *Өстенә әйбәт язгы пальто, башына эшләпә кигән Вилдан, бераз алдарак, өстенә зәңгәр пальто, башына ак шапка кигән Миләүшә күренде.* Г.Әпсәләмов

2) Газета-журнал һ.б.ш.да уртак темага багышланган берничә мәкалә өчен уртак, гадәттә зур хәрефләр белән басылган гомуми башлык. *Газетаның чираттагы санын планлаштыра башладылар. --- – Бу санга нинди шапка куябыз? – диде Шакир абый ---.* Р.Фәизов

3) *махс.* Китапның титул битендә һ.б.ш.да башлык астында күрсәтелә торган басып чыгаручы учреждениенең яки сериянең исеме. *Анда озак кына даими экспозициядә торды. Музей шапкасы астында басылып чыккан открыткалар сериясенә дә кергән иде ул.* Б.Гыйльванов

4) Интернет сайты, телевизион тапшыру, мәгълүмат чаралары кебекләрдә гомуми мәгълүмат, кереш сүз һ.б.ш. бирелә торган өлеш. *Сайтларның шаблоны бер үк, әмма адресы, эчтәлеге, шапкасының дизайны – барысы да индивидуаль.* Д.Сәфәров. *Журнал бик озак еллар мин ясаган шапка белән чыкты.* Сөембикә

5) Берничә көлтәдән торган өем; көлтәләрнең шул өемгә куелу рәвеше. *Менә, бер чама ургач, бәйләнгән көлтәләр шапкаларга утыртылды. «Урак эшләре» тәмам булгач, көлтәләр шапкалардан алынып торыпша өстенә ташланды һәм чабагачлар эшкә кереште.* З.Мурсиев

**ШАПТАЛАП** *и. диал. к.* **шапылдавык** (3 *мәгъ.*)

**ШАПТЫРДАТУ** *ф.* Шаптыр-шоптыр китерү, берәр нәрсәдән шаптыр-шоптыр иткән тавыш чыгару. *Шаптырдатып су ерып бару*

**ШАПТЫРДА́У** *ф.* Шаптыр-шоптыр килү, шаптыр-шоптыр иткән тавыш чыгару. *Симез балыкларны өркетеп, суда нидер шаптырдады.* З.Мурсиев. *Шаптырдаган тавышны ишеткән милиционер, тоткын суга сикерде дип, шул тарафка пистолетыннан ата башлаган.* Кызыл таң

**Шаптырдап калу** Шаптырдарга өлгерү. *Кемдер кычкырган кебек булды, нәрсәдер шаптырдап калды.* З.Мурсиев

**ШАПТЫРДАШУ** *ф. урт. юн. к.* **шаптырдау**

**ШАПТЫ́Р-ШОПТЫР** *иярт.* 1) Суны, сазлыкны ерып атлап барганда, чумганда, көчле бәреп чәчрәткәндә чыккан чупырдау, чапылдау тавышын белдерә; чапыл-чопыл. *Әлмә киргәксә – әлмә табасың, имән урман яме булып утыра; бездә урманнан җиләк исе килеп тора. Ә монда, тфү, һәр үскән агач деловой икән, аяк мүккә урала, шаптыр-шоптыр су ерасың.* К.Кара. *Янәшәдә генә шаптыр-шоптыр балык уйный.* Х.Галидән

2) Артык ашыгып, авызны зур ачып, шапылдатып ашаганда чыга торган тавышны белдерә. *Тегермәне тарта тора, Хәрәкәт арта тора, Ашау машинасымыни: Аны-моны, аннан-моннан, Хаптыр-хоптыр, Шаптыр-шоптыр Капты-йотты!* Ш.Галиев. *Авыздагы ризыгын Шаптыр-шоптыр чәйнәгән. Сүз әйтергә теләсә, Теле көчкә әйләнгән.* Ф.Яруллин

3) Яссы әйберләрне бер-берсенә бәргәндә, каеш, тукыма һ.б.ш.ны кисәк селтәгәндә барлыкка килгән, һаваны шартлаткан тавышны белдерә. *Авыл советы йортының түбәсенә Мәрдәнша Мурзин үз кулы белән кадаган ал байракны җилләр шаптыр-шоптыр китереп какты.* Г.Ахунов

**ШАПТЫ́Р-ШОПТЫР ИТҮ** *ф. к.* **шаптырдау**

**ШАПТЫ́Р-ШОПТЫР КИЛҮ** *ф. к.* **шаптырдау**. *Аяктагы итек суда шаптыр-шоптыр килә.* Казан утлары

**ШАПШАК** *с.* **1.** 1) Үзе, киеме чиста булмаган, гомумән чисталыкны сакламаган, пөхтәлек хас булмаган, җыйнаксыз (кеше тур.). *Урамыбызда иң тыныч, иң сүлпән, иң шапшак хатын Мәрхәбә кодагый иде.* М.Кәрим. *Әйтәм аны мәзин абзый муеннарын, колакларын юмыйча йөри торган шапшак малайларны «хинзир!» дип сүгә, тикмәгә генә түгел икән.* Г.Бәширов

2) Ару булмаган, пычранган, керләнгән, пычрак. *Җиту чәчле, шапшак куллы сузан бер малай, ыбыр-чыбырларны куркытып, олырак балыкларын җыеп йөри икән.* А.Гыйләҗев. *Мондый шапшак, мескен тракторнымы, әллә аның бичара хуҗасынмы кызганырга белмичә, бригадир аптырап сызгырып җибәрде.* Н.Фәттах

3) *күч.* Аннан-моннан эшләнгән, җиренә җиткерелмәгән, кимчелекле. *Теге яисә бу әсәрнең теле ярлы икән, шапшак һәм төссез икән, бу – авторның наданлыгыннан яки ялкаулыгыннан килә.* Г.Бәширов

4) *күч.* Әдәпсез, тупас, ямьсез, сүгенүле (тел, сөйләм тур.). *– Син, тәрбияләсәң, юньләп тәрбиялә, алай шапшак сүзләр әйтмә, – диде ул.* А.Тимергалин. *Мөсәгыйть бу уңайдан үз телендә булган бөтен шапшак сүзләрне файдалана ---.* М.Мәһдиев

5) *күч.* Кара эчле, мәкерле, түбән, начар, яман (кеше тур.). *Үзебезнең татар Зоммерлары, Хромосомнары, Икзимнары, Фикция Саматовналары рухи шапшаклар, милләтнең корткычлары итеп күрсәтелә.* Шәһри Казан

6) *күч.* Гаделсез, явызлык тулы, гаделлек булмаган. *Син әле белмисең: бик шапшак бу дөнья.* М.Мирза

**2.** *и. мәгъ.* 1) Чисталык сакламаган кеше. *Бала табарга керүче хатыннар арасында иң чисталары татар хатыннары иде, тик соңгы вакытларда алар арасында да шапшаклар күренә башлады, дигән иде алар.* Т.Миңнуллин. *Юынгыч килеп чыга, Шаккатып башын кага: Аһ син, шапшак, аһ син пычрак, Чучка – шакшыга баткан!* Р.Корбан

2) Һәртөрле кер, шакшы, пычрак. *Ерганак үзәнгә ташый Күпме пычрак, күпме шапшак.* З.Нури. *Тикмәгә генә, үткәнеңә төкерсәң, киләчәгең сине шапшакка батырыр, димәгәннәрдер.* М.Хәсәнов

3) *күч.* Түбәнлек, явызлык, мәкер

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Пычрак хәлдә, чисталык сакламыйча, чисталык булмый торып. *Тамара белән сүз көрәштергән арада, шапшаграк киенгән бер хатын безнең яныбыздан үтеп китте.* Ф.Яруллин. *Әйдә, ярар әле, дип шапшак йөрү анда юк, бу Финляндиядәге гомуми тәртипкә дә туры килә.* С.Ибраһимова

2) Аннан-моннан, җиренә җиткермичә, җыйнаксыз гына

3) *күч.* Явыз рәвештә, астыртын явызлык белән

**ШАПШАКЛАНУ** *ф.* 1) Шапшак кешегә әйләнү, чисталыкны сакламый башлау, җыйнаксызлану, пөхтәлеге бетү. *Өйдә тәртип бугай. Шапшакланмагыз, тәртипле генә яшәгез.* З.Хәким

2) Керләнү, пычрану, пычрак, шакшы хәлгә килү. *Иртәнге ак бураннар Кичкә шапшакланганнар: Корымга уралганнар, Сөремгә буялганнар ---.* Ш.Галиев

**Шапшакланып бетү** Тәмам шапшаклану. *囗囗Эштә шапшакланган киемне салып кую. Фани дөнья буйлап йөрийөри Шапшакланып бетсәм әгәр дә, Чистарырга бик тиз кереп китәм – Бер җирдә бар шундый мәгарә.* И.Гыйләҗев

**Шапшакланып китү** Соңгы вакытта сизелерлек шапшаклану. *Элек гел чиста тора торган өстәл өсте генә килен төшкән көннән бирле шапшакланып китте: ашап төкерелгән көнбагыш, чикләвек чүпләре, эчеп бетмәгән чәйле әллә ничә чынаяк, бөгәрләп аткан салфеткалар.* Сөембикә

**ШАПШАКЛЫК** *и.* 1) Кешенең гадәтләрендә чисталык, җыйнаклык, пөхтәлек җитмәү үзлеге; шапшак булу сыйфаты, җыйнаксызлык. *Бездә дә табигать бик матур. [Нәҗип Газизов] Гадел булды һәм безне дә намуслы, сәләтле, хезмәт сөючән, тырыш итеп тәрбияләргә омтылды. Тәртипсезлеккә, шапшаклыкка, алдашуларга юл куймый иде.* Л.Шәех. *Хатыннарның берсе шапшаклыкта, икенчесе ялкаулыкта гаепле булып чыкты.* Р.Хәсәнова

2) Берәр җирнең, берәр нәрсәнең керле, пычрак булуы, чисталык булмау, пычраклык; пычратылу күренеше. *Ләкин үзебезнең шапшаклыгыбыз күп җиргә йогып кала.* Ф.Яруллин. *Буфетта шапшаклык, тәртипсезлек хөкем сөрә.* З.Зәйнуллин

3) Берәр эштә җентеклелек җитмәү күренеше, төгәлсезлек. *Аннары телен дә бер карап чыгасың бар. Синең язганнарың элек бик җанлы була иде. ә бу повестеңда, турысын әйткәнгә гафу ит, нииндидер шапшаклык сизелә.* Ф.Садриев. *Беренче елларда язылган әсәрләремне янә укып карыйм мин. Укып карыйм да Роберт Батуллин исемле башлап язучыны сүгәм. Тел шапшаклыгы, гәзит тәгъбирләре, ясалма инверсияләр ачуны китерә.* Р.Батулла

4) *күч.* Кеше холкындагы түбәнлек, явыз ниятлелек, вөҗдансызлык, әшәкелек; яман гамәл, явызлык. *Нинди генә вакыйгаларны сурәтләсә дә, кемнәрне генә әсәрләренә кертсә дә, анда һичнинди шапшаклык, пошлость юк.* Т.Миңнуллин. *Иптәшеңнең никахлы ирен тартып алу кебек бозыклыкны, әхлаксызлыкны, шапшаклыкны мин күз алдыма китерә алмый идем, авызым пешкәнче.* Т.Галиуллин

**ША́П-ШАП** *иярт.* Ритмик рәвештә, тигез кабатланып торган шап иткән тавышны белдерә. *Суыкка бирешмәс өчен, сугышчылар баскан урында биеделәр, бияләйләрен шап-шап суккаладылар.* Г.Әпсәләмов. *Сафия йодрыгы белән шап-шап утыргыч кыйнады.* Н.Гыйматдинова

**ША́П-ШОП** *иярт.* Әледән-әле, тигезле-тигезсез рәвештә кабатланып торган шап иткән тавышны белдерә. *Кар базының капкачы бертуктаусыз шап-шоп ачыла да ябыла – аннан өйгә чүлмәк-чүлмәк сөт, май, каймак ташыйлар.* Ә.Еники. *Бакалар ары шапшоп, бире шап-шоп сикерешә.* Р.Батулла

**ШАПЫЛДАВЫК** *и.* **1.** 1) *к.* **шапалак** (*1 мәгъ.*). *Сагалап тора, качып сагалый, үрмәләп тә бара, шуышып та якынаеп карый, юк, чебен үзенекен итә: шапылдавык астында үләсе килми.* Р.Батулла

2) *к.* **шакылдавык**. *Бакчада шапылдавыгын шакылдатып булса да ятадырые.* Н.Фәттах. *Шапылдавыклар шакылдый, тырылдавыклар тырылдый һәм башка төр уен кораллары уйный башлый.* Р.Мостафин

3) Йон, мамык кебек нәрсәләрне язу, кылдан арындыру һ.б.ш. өчен еш тешле тарак рәвешендәге гади эш коралы. *Махсус тараклар, үзе әйткәнчә, шапылдавыклар аша үткәрә [мамыкны].* Шәһри Казан

4) Кыска кәгазь торба рәвешендәге, филтәсеннән тартып ертып җибәргәндә һаваны шартлата торган уенчык; *русчасы:* **хлопушка**. *Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәре алдыннан мондый тикшерүләр инде гадәткә кергән, чөнки бу вакытта кибет киштәләрендә төрле төрдәге пиротехника (петарда, шапылдавык, фейерверклар) пәйда була.* Яңа Чишмә хәбәрләре

5) Гадәттә, яланаякка киелә торган артсыз, үкчәсез ачык аяк киеме; чәпелдек; *русчасы:* **шлёпанцы**. *Илләре бик хәерче – экскурсияләрдән кайтышлый да аңа шаккатып, тел шартлатып кайтырлык. --- Өсләрендә – үзләре типчегән капчык-киемнәр, аякларында – үзләре әтмәлләгән шапылдавыклар (шлёпанцылар).* Г.Җәлилова

**2.** *с. мәгъ.* Шап-шоп иткән тавышлар чыгара, шапылдый торган. *Зиннәт озын мыеклы абыйның үзен генә түгел, аның шул шапылдавык галошын да, хәтта аның кулындагы чөмәкле таягын да яратмый.* А.Шамов

**ШАПЫЛДАТУ** *ф.* 1) Шап иткән тавыш чыгару, шап-шоп китерү. *Ул кабарып киткән сумкасына шапылдатып сугып алды.* Н.Әхмәдиев. *Учны учка шапылдаткач, Барый, җилкенеп, урыныннан кузгалды ---.* А.Гыймадиев

2) Кискен хәрәкәт белән каты итеп сугу, бәрү. *Капка түпләрендә аттан сикереп төште һәм, йөгәнен салдырып, айгырның артына берне шапылдатты.* А.Гыйләҗев. *Шулчак кул үзеннән-үзе алдагы партада утырган кызның озын чәч толымына үрелә, сыйныфташ кыз да төшеп калганнардан түгел – борыла да кулындагы китап белән маңгаеңа шапылдата.* З.Хөснияр

3) Иркәләү, шаярту һ.б.ш. рәвешле кагу, каккалау. *– Ирек бирмәдең бит, брат, ә! – дип, мин дустымның иңбашын шапылдатып алдым.* З.Хөснияр. *– Я, егет, кызлар озата башладыңмы инде? – дип, аның аркасын шапылдатты.* Г.Әдһәмова

4) Ямьсез итеп, тавышлар чыгарып ашаганда, эчкәндә авызны чапылдату. *«Шапылдатма, эти», – ди малай. «Тынычрак аша, эти», – ди килен...* А.Гыйләҗев. *Тагын да бала булса, кайнана аны да авызын шапылдатып ашарга, сүзләрнең азагын йотып сөйләшергә өйрәтер, телен дә «әннә» дип түгел, «әббә» дип ачтырыр дип уйлады.* М.Маликова

5) Бер сугуда, бәрүдә, атуда егу, тәгәрәтү; үтерү. *Ә чит илләрдәниләр булып ята бүген? Патрис Лумумбаны шапылдаттылар әнә...* Ә.Мушинский. *Әйе, ә теге черки нәкъ шул кызыл ыштан кырыена кунган, шунда шапылдаттым да инде мин аны!* Э.Яһудин

6) Тиз, кыю, җитез һ.б.ш. рәвештә берәр өслеккә нәрсәдер беркетү, сугу, язу, ябыштыру. *– Тукта әле, түтекәй, Александр дигәне янына Имаметдинен куярга оныткамнмын, әкәмәт! – дип көлеп җибәрде һәм зур хәрефләр белән үзебезчә исемен шапылдатуын күреп тордым.* М.Хуҗин

7) Нәрсәне дә булса бер-бер артлы эшләп, әзерләп тору, бик тиз һәм күпләп чыгару. *Хикәяләрне шапылдата гына бу язучы* // Тиз генә, аннан-моннан эшләп ату. --- *интервьюны бүген үк шапылдатабызмы?* Н.Гыйматдинова. *Әфсен-төфсенләп, норманы шапылдаттык.* Т.Нәҗмиев

8) Берәр кешегә карата нииндидер җәзага тарту, шелтәләү һ.б.ш. турында карар чыгару; чәпәү, сылау. *Бүреләрнең тамагы туйгандырмы-юкмы, әмма Мекебайга биш елны шапылдатканнар.* Н.Әхмәдиев

**Шапылдатып алу** Бер мәртәбә яки аз гына вакыт шапылдату. *Комбат учын учка шапылдатып алды, димәк, кәефе күтәрелә.* С.Шәрипов. *Капитан үзе дә сизмәстән үрә катты, башка солдатлар да үкчәләрен шапылдатып алдылар да тораташ булдылар.* Р.Батулла

**Шапылдатып карау** Сынау өчен шапылдату. *Таймас: – Симереп бетәм инде! – дип, корсагына шапылдатып караган иде, әбисе: – И инде, күз төпләрең күп-күмгәк, бер дә төс керми... Беләкләрең дә сыеграк, малай кешегә килешми, – дип, авызын томалады.* А.Тимергалин

**Шапылдатып кую** Бер мәртәбә яки кисәк шапылдату. *Ситсының әле яшелен, әле бишниен, әле кызылын суырып алалар. Алалар да җәеп салып, әле кулдары белән шапылдатып куялар, әле беләкләренә эләләр дә кояшка ялтыратып мактарга тотыналар.* Г.Бәширов. *Шул арада йомры гына гәүдәле каракучкыл дневальный пәйда булды, кыланган сыман, башын артка ташлабрак честь биргәч, үкчәләрен шапылдатып куйды.* С.Шәрипов

**Шапылдатып тору** Берөзлексез, даими яки хәзерге моментта шапылдату

**Шапылдатып утыру** *сөйл. к.* **шапылдатып тору**. *Яшеренеп торуның мәгънәсе калмаган, Ялмавыз да үз кыяфәтенә кайткан, әрекмән яфрагыдай колакларын шапылдатып утыра башлаган.* Г.Гыйльманов

**ШАПЫЛДАТЫП** *рәв.* Катгый рәвештә, икеләнмичә, кистереп; тәвәккәлләп. *Илаһи азык таләп иткән җанымның ишекләрен мөгаллимәм өчен шапылдатып бикләп куйдым.* Ф.Яхин. *Без аны да шапылдатып президент итеп сайлап куйган булыр идек.* Н.Шәрифуллин // Усалланып, явызланып

**ШАПЫЛДА́У** *ф.* 1) Шап итү, шапшоп килгән тавышлар чыгару. *Нәрсәдер шапылдый, шыгырдый, кемнәрдер кычкыра, сүгенә, берьюлы бер көтү эт өрә иде.* Г.Бәширов. *Капка аның кулыннан ычкынып, шапылдап ябылды.* Ә.Хәсәнов

2) Шундый тавыш чыгарып килеп төшү, бәрелү, егылу, аву һ.б. *Мин утырам да утырам, берзаман буран аша капка шапылдавы ишетелде.* А.Гыйләҗев. *Кинәт Марсның кәшәкәсе, кулыннан ычкынып, идәнгә шапылдый.* Л.Лерон // Кискен рәвештә, кинәт килеп төшү, бәрелү, егылу, аву һ.б.ш. *Актаң чәрелдәп куя да куркуыннан шапылдап утыра.* Г.Каюмов

3) Ямьсез итеп, тавышланып ашау, эчү; чапылдау. *Тәмле ризык кергәч, авыз үзеннән-үзе шапылдый инде, аны тыеп булмый.* А.Гыйләҗев. *Акча алу юк, эчәргә булса – җиткән. Анысына шапылдап торалар, аракы булмаса, әчегән балга да ризалар.* Ә.Әминев

4) *куч.* Артык күп сөйләү, лыгырдау, телгә салышу; кирәкмәгәнне сөйләү. *Әй, сиңа әйтәм, кияү килгәч, тагын син шапылдама, ул үзе ясый башламасын!* Г.Гобәйдуллин. *Юкны шапылдамасана! Адәм көлкесе! Әйтер сүзең булгач, кеше артына посып әйтмә, каршысына барып әйт!* Г.Бәширов

**Шапылдап йөрү** Теләсә кайда һәм теләсә кайчан шапылдау; озак вакыт дәвамында шапылдау. *Кулыңа ике айлык пенсияң берьюлы килеп кергән икән, нигә инде бу хакта шулкадәр шапылдап йөрергә?* Р.Фәизов

**Шапылдап кую** Кисәк, бер мәртәбә шапылдау

**Шапылдап тору** Бертуктаусыз, гел шапылдау; хәзерге моментта шапылдау. – *Тиз бул! – дип кычкырды. – Күп шапылдап торсаң, җәяү генә барырсың.* Г.Бәширов. – *Ичмасам, шешә башы күрсәткәнгә дә исе китми бит, бүтән лесниклар шикелле аракы дигәндә авызы шапылдап тормый чукынчыкның, – диде сул як күрше Закир абзый.* М.Галиев

**Шапылдый башлау** Шапылдарга тотыну. *Өйдән җавап булмагач, тагын ишек-тәрәзәләр шапылдый башлады.* И.Хуҗин. *Ябалак инде хәлсезләнде, канатлары сирәгрәк шапылдый башлады.* Н.Каштанов

**Шапылдый тору** Билгеле вакыт шапылдау. *Алланың рәхмәте, суга кереп үскән агач төпләрендә Сарбай белән бераз шапылдый торгач, картның күлмәгенә берничә балык йөзеп керде.* Ф.Бәйрәмова

**ШАПЫЛДЫК** *и.* 1) Шап-шап иткән тавышлар чыгара торган берәр нәрсә. *Шап-шап шапылдык, Басма өстендә тапылдык.* Табышмак

2) *к.* **шапылдавык** (*3 мәгъ.*). *Хәзер шапылдык белән шапылдаталар.* Милли-мәдәни мирасыбыз: Оренбург өлкәсе татарлары

3) *куч.* Артык сөйләмчәк кеше, лыгырдык, тел бистәсе. *Бу – безнең Гариф Шабаев дигән егет. Бик [җитди], бер дә шапылдык түгел.* Ш.Маннур

**ШАПЫРДАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **шапырдау.** *Рәгыйдәнең су шапырдатуын күңелне иркәләгән рәхәтлек белән тыңлап, аның сөртенүен шундый ук җылы хис белән күзәтте.* Ә.Баян. *Атуын атасың, камыш арасыннан алып чыгуы бәла үрдәкне, әнә шунда минем Салпыколагым шапырдатып күлгә кереп китә дә һайт дигәнче, авызына кабып алып та чыга.* Г.Якупова

2) Ашаганда яки эчкәндә, һава белән суырып, шапыр-шопыр иткән тавыш чыгару. *Нигә шултикле шапырдатып ашыйсың?* Х.Камалов. *Чынаякка балкашыкның бәрелүе һәм Эльвирның чәйне шапырдатып чөмерүе дә сискәндереп җибәрә иде.* М.Маликова

**Шапырдатып алу** Бераз гына шапырдату. *Я ул ишек төбендә башын сыртына салып йоклап ята, я йорт алдында бәпкә үләнен ялкау гына йолкып әрле-бирле йөренә, тагаракка салып калдырган суны, килеп, борыны белән шапырдатып ала ---.* Ә.Еники

**Шапырдатып тору** Бертуктаусыз шапырдату

**ШАПЫРДА́У** *ф.* 1) Берәр сыеклык көчле агым белән акканда шыбырдау, шабырдау, гөжләү. *Хатын капылт кына кулларын ычкындырып, диваннан торып басты да, чәч-башын төзәткәли-төзәткәли, ишеге ачык торган ванна бүлмәсенә кереп бикләнде, аннан шапырдап су аккан тавыш ишетелде.* З.Хөснияр. *Бераздан яр буена урнашкан тирмә эчендә су шапырдаган, хатын-кызлар чәрелдәшкән тавышлар килә башлады.* Р.Сәгъди

2) Берәр сыеклык көчле кайнаганда, болгатканда, ерып атлап барганда шапыр-шопыр итү; чапырдау, чапылдау. *Ярдан сиер егылып төшкәндәй, зур-зур балыклар шапырдый.* Р.Батулла. *Тансык, --- сазлыкта пычтыр-пычтыр килеп, тездән батып, сары чәчәкле үләннәрне дә өзде. Җәй булса, шапырдап йөзеп тә килер иде.* М.Рәфыйков

3) *к.* **шабырдау** *(5 мәгъ.)*. *Чуаш карчыгы шул җәһәннәм кызуы кебек мунча ләүкәсендә өстеннән шапырдап тир аккан, хәле бетеп, һушыннан язар чиккә җиткән кызны һаман туктаусыз әйләндерде; әйләндерде-әйләндерде дә, карт сөяк тезләре белән кызның эчен үтерердәй авырттырып, чәнечтереп басты, изде.* Г.Ибраһимов

4) *күч.* Артык күп сөйләшү; буш сүз сөйләү. *[Салих:] Күп шапырдама, чишен дигәч чишен!* К.Тинчурин

**Шапырдап тору** Әле хәзер шапырдау. *– Кашык белән болгатканда да сизелә ул, – ди оста үзе. – Әзер ширбәт су кебек шапырдап тормый, сузылучанга әйләнә башлый.* Сөембикә

**Шапырдый башлау** Шапырдарга тотыну

**ШАПЫРДАШУ** *ф. урт. юн. к.* **шапырдау.** *Фатыйма ---, тотыласы балыкларның букчасында шапырдашуын ишеткәндәй булып, кыш буена хыяллана, табада сөякләренә хәтле эретеп кыздырыласы балык исен җир ачыла башлаганда ук бөтен җаны белән сизә иде.* Ә.Гаффар

**ШАПЫРМА** *кис. к.* **шабыр**. *Өстәлдәге татлы ризыклар белән сыйланып, шапырма тиргә төшеп чәй эчкәннән соң, Сәйфетдин Куба портында «Муса Җәлил» исемле совет теплоходының икенче штурманы Рафаэль атлы шаян холыклы бер татар егете белән танышуын да сөйләп алды.* А.Хәсәнов

**ШАПЫРТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **шапыру**

2) *сөйл.* Арттырып сөйләү, сөйләгәндә ялган кушу. *Шапыртасың бугай*

**ШАПЫРУ** *ф.* 1) Интенсив рәвештә болгатып күбекләтү, күпертү. *Бай хуш килдегезне әйтте; тукал кереп, ишек төбендәге зур сабаны пешкәк белән берничә кат шапырды да өлкән табак белән Сарсымбайның алдына кымыз һәм берничә савыт китереп куйды.* Г.Ибраһимов

2) *күч. к.* **шапырыну.** *Сезне белмим, мин үзем утта янмаячакмын, суда батмаячакмын, барыбер керәчәкмен дип тә шапырды бугай. Мени баттың да. Физика бит ул!* Ф.Садриев

**Шапырып йөрү** Озак вакыт шапыру. *Белмисең, милләт, синең хакың өчен нинди җырлар ул егет шапырып йөри.* Г.Тукай

**ШАПЫ́Р-ШОПЫР** *иярт.* Су яки башка сыеклыкны көчле болгатканда, ерып барганда, кайнатканда, суырып эчкәндә һ.б.ш. очракларда барлыкка килгән тавышны белдерә. *Ильяс, суга кереп, яңадан шапыр-шопыр атларга, аннары йөзәргә кереште.* Ә.Баян. *Малайлар, унбиш-егерме адым түбәнрәк китеп, шапыр-шопыр балык куа.* Г.Сабитов. *Бот кимерә иде ире шатыр-шотыр, шулпа чөмерә иде хатыны шапыр-шопыр.* Ф.Яруллин

**ШАПЫ́Р-ШОПЫР КИЛҮ** *к.* **шапырдау**. *--- вак шомырт куакларын ера-ера, һаман эчкәрерәк үтте. Аның саен сазлык сыегая бара, кирза итекләр астында саз суы шапыр-шопыр килә.* Г.Рәхим

**ШАПЫРЫК** *с.* **1.** *к.* **шапырынучан**. *Шапырык кеше*

**2.** *и. мәгъ.* Мактанчык кеше, шапырынырга яратучы. *Шапырыкның арты ерык.* Әйтем

**ШАПЫРЫЛУ** *ф.* 1) Ургылу, ташкын булып агу. *Мартта – шарт, апрельдә шапырыла.* Әйтем

2) *күч.* Күпләп, актарылып килү, артык күп һәм еш булып тору, басып китү. *Бәла килсә, шапырылып килә.* Әйтем

**ШАПЫРЫНДЫК** *с. сөйл.* 1) *к.* **шапырынучан**. *[Янбалит] ифрат та ялганчы, җилкуар, шапырындык бер кеше иде.* Ш.Еникеев

2) *к.* **шапырынкы**. *Нинди шалтыравык, нинди шапырындык сүзләр!* Н.Фәттах

**ШАПЫРЫНКЫ** *с.* Шапырынудан, мактанудан гыйбарәт булган, артык һавалы; күпертелгән, арттырылган. *Вышка рәсеме астында газета хәбәрчесенең шактый шапырынкы сүзләре урнаштырылган иде.* М.Хәсәнов. *Җыен шапырынкы сүзләр язып тутырган да шуны, акыллы сүзләр яздым, дип белә инде үзенчә.* Р.Төхфәтуллин

**ШАПЫРЫНУ** *ф.* Үз шәхесенең, эш-гамәлләренең әһәмиятен арттырып күрсәтергә тырышу, мактану, артык күпертеп сөйләү. *Мөһим бер вакыйга турында төпле, тыйнак кына итеп язасы урында, кызганычка каршы, әнә шулай чаманы белмичә шапырынып язганмын икән шул мин дә!..* Ә.Еники. *Ерактан гына күреп калса да, без аның белән бер мәҗлестә утырдык, фәлән-төгән дип шапырынырга ярата.* Х.Камалов

**Шапырына башлау** Шапырынырга тотыну

**Шапырынып алу** Бераз гына, бер ара шапырыну. *Әле шушы көннәрдә генә Русиянең авыл хуҗалыгы министры Гордеев Италия башкаласы Римда: – Безнең ил өч Европаны яки бер миллиард кешене туйдыра ала! – дип шапырынып алды.* А.Галимов

**Шапырынып йөрү** Төрле җирдә, төрле вакытта шапырыну. *Дошманнарның барлыгы: «Җәләл мулла угылларын мактап, шапырынып йөргән булган иде. Ничә ел йөреп, адәм рәтле урынга да керә алмадылар», – дип көләчәк.* Г.Ибраһимов. *Башбаштакланып, кала халкына: «Сез бүгеннән миңа ясак сала башларсыз», – дип шапырынып йөргән.* М.Хәбибуллин

**Шапырынып кую** Бер мәртәбә, көтмәгәндә шапырыну. *Бу дөньяда медицина бик көчле икән, дидем. Конспирация өчен, дип шапырынып куярга да онытмадым.* А.Тимергалин. *«Мәгәрич» дигән булып, теге ике алтын тәңкәне дә калдырды. «Миндә ул күп, урманда яшерелгән» дип шапырынып та куйды.* Г.Гыйльманов

**Шапырынып тору** Даими яки әледән-әле шапырыну; хәзерге моментта шапырыну

**Шапырынып утыру** *сөйл. к.* **шапырынып тору**. *Соңгы акчасын чыгарып бирмәгәндер әле, байлыгы белән шапырынып утырды бит.* Р.Габделхакова

**ШАПЫРЫНУЛЫ** *с.* Мактанулы, күпертеп сөйләнә торган. *Монда тормыш арифметикасы бик гади, монда шапырынулы сүзләр юк.* М.Мәһдиев

**ШАПЫРЫНУЧАН** *с.* **1.** Артык мактанчык, шапырыну гадәте булган. *Экичеләр кызыл сүз сөйләүчән, газета белән*

*шапырынучан булалар.* Х.Камалов. *Шагыйрь халык хакын даулауны башкарак вазифалар эчендә күрә. Хәтта шапырынучан бәндәдәй күкрәк сугып, үзен хадим итеп тә санамый.* Зиннур Мансуров

**2.** *и. мәгъ.* Үтә мактанчык кеше. *Шапырынучан башына бәла шапырылучан.* Әйтем

**ШАПЫРЫНУЧАНЛЫК** *и.* Шапырыну гадәте, мактанчыклык

**ШАПЫ́-ШОПЫ** *иярт. к.* **шап-шоп**. *Исхак кече капканы ачык калдырып чыгып киткән, яңгыр җиле капканы шапы-шопы бәргәләп тора иде.* А.Гыйләҗев. *Пароходның урта бер җирендә, аста, канатлары белән шапы-шопы суга бәрә-бәрә, иләмсез зур көпчәк әйләнә.* М.Хәсәнов. *Төзүчеләр, ыгы-зыгы килмичә генә, шапы-шопы кул чабып алдылар.* Җ.Рәхимов

**ШАПЫ́-ШОПЫ ИТҮ** *ф.* Шапылдау

**ШАПЫ́-ШОПЫ КИЛҮ** *ф. к.* **шапы-шопы итү**

◊ **Шапы-шопы китерү** *к.* **шапылдату** (*1 мәгъ.*). *Тын гына шәл бәйләп утыручы килен яки кыз бервакыт күкрәк тутырып бер сулыш ала да борын астыннан гына көйли башлый. Шуны гына көткән гармунчы да гармун телләренең сөякләреннән шапы-шопы китереп бармак шудырып ала һәм эргәгә керә.* М.Мәһдиев. *Авылның иң чибәр кызы Гөләндәм ялтыравыклы башмакларын шапы-шопы китереп биеп ята.* Ф.Яруллин

**ШАР** I *и. рус мат.* **1.** 1) Ярымтүгәрәкне үзенең тотрыклы диаметры тирәсендә әйләндерүдән барлыкка килгән геометрик җисем; пространствода үзәктән бер үк ераклыкта урнашкан нокталар хасил иткән геометрик җисем. *Берсенең баш киеме биек конусны хәтерләтә. Конусның өстендә сары төстәге шар калкып тора.* Н.Фәттах. *Шар кебек түп-түгәрәк ун айлык малай алпан-тилпән йөри, мин сиңа әйтим, ишегалдын икегә яра бу!* А.Хәсәнов. *Шарның диаметры. Шарның мәйданы күләмен исәпләү*

2) Шундый формалы, шуңа охшаш, шуңа якын йомры предмет. *Сигезенче март бәйрәменә ул Алтынчәчкә гаҗәеп бүләк китерде: йодрыкка сыярлык тимер шар матур итеп чентәрләнгән, аның эчендә шулай ук чентәрләнгән тагын бер шар тәгәрәп йөри.* М.Маликова. *Сабын күбеге һавада очканда, гаҗәеп матур шар була. Могҗизалы шарда салават күпере төсле йортлар, тәрәзә шәүләләре күренә. Шул шарны тотып карыйсы килә.* Р.Батулла

3) Чыршыны бизәү өчен шундый формада матурлап, бизәп эшләнгән уенчык; чыршы уенчыгы. *Әй чыршы, нәни чыршы, Сине кайчан аңларбыз? Бер көнлек бәйрәм өчен Сине кисеп алабыз. Уенчык шарлар асып, Түргә куеп бизибез.* Э.Шәрифуллина. *Чыршы очына матур гына бер күркә беркетәбез, аның урасына кечерәк бер шар яки сәйлән ябыштырабыз – йолдыз булып янып торсын!* Сөембикә

4) Эченә һава тутырып, уенчык яки бәйрәм, туй һ.б.ш.да бизәү элементы буларак файдаланылган, төсле юка резин яки башка материалдан ясалган куык. *Галия белән Миненур шар кабарта башлыйлар.* Д.Салихов. *Керпе кунакка килгән һәм энәләре белән ялгыш бөтен шарларны шартлатып бетергән.* Л.Закирова

5) *сөйл.* Кайбер спорт уеннарында кулланыла торган кечкенә каты туп; гомумән шундый уенчык. *Кәшәкәле уйнау белән шулкадәр мавыкканнар, шар артыннан туктаусыз чаба торгач, чит-читләре юп-юка челтәр боз белән капланган бәкегә таба җилдергәннәрен сизми дә калдылар бугай.* Р.Камалетдинова

6) Кайбер изафәле тезмәләр составында кулланылып, «сфера, түгәрәк формадагы җисем» мәгънәсен белдерә. *Ул [Генрих Гейне]: «Әгәр Җир шары чатнаса, аның чатнавы шагыйрь йөрәге аша үтәргә тиеш», – диган.* Н.Нәҗми. *Яшь хыялыйның һава шары шартлый, шарга төялгән спортчылар сазга чума.* Р.Батулла

7) *иск.* Сайлаулар вакытында тавыш бирү өчен кулланылган йомры таш яки башка шундый әйбер. *Кандидатларны шар белән сайлый башлыйлар.* Г.Тукай

8) *иск.* Сайлауларда билгеле кандидат яклы бирелгән тавыш. *Илнең теләгәне табылды: Сарсымбай үндүрт шар артык алды!* Г.Ибраһимов. *Анда сиңа шар салырлар, шарны күбрәк җыйсаң – Берлектә.* Х.Ибраһим

**2.** *с. мәгъ.* Түм-түгәрәк. *Тамак астын дер-дер калтыратып, шар күзләрен ачкалап-йомгалап, егет белән кызга карап торды.* Г.Мөхәммәтшин. --- *Кадерҗан чәче чалгыдан ясалган үткер пәке белән кырып алынган шар башына иске түбәтәй чәпәгән* ---. А.Хәлим

◊ **Шар куу** *к.* **шар сугу**. *Тимераякта куыша-узыша, үсмерләр шар куа.* Р.Камалетдинова. *[Хәтимә:] Шушы вакыткача шар куып кына йөргән егет түгел, димәкче булам.* Э.Яһүдин. **Шар салу** 1) Сайлауларда катнашып тавыш бирү. *Староста итеп сайлаганда, үзең шар салдыңмы? Хәзер халык алдында татарлар йөзенә кара ягаргамы?* Г.Сабитов. *Мондый бюллетеньгә, әлбәттә, шундук кара шар салалар. Шул булдымы исем, шул булдымы академик?* М.Мәһдиев; 2) Билгеле кандидатны сайлау, шуның өчен тавыш бирү. *Борынгы ханнарның, солтаннарның баласы, Чыңгызның нәселе, аксөяк Якуп бар чагында, минем кебек җылкы көтеп үскән кара казакъ Этбай улы Сарсымбайга шар салырга мин исәрме?* ---. Г.Ибраһимов. *Әгәр халык аларны ярата икән, аларга шар салырлар, аларны сайларлар.* Г.Исхакый. *Биим дисәм күркем бар. Җаным тарткан кандидатка Шар салырга иркем бар.* М.Саттаров. **Шар сугу** 1) Кәшәкә таяк белән кечкенә туп яки шар формасындагы башка берәр әйберне сугып йөртүдән гыйбарәт, чирәм хоккеена охшаш уен һәм шуны уйнау. *Аның каравы эш-шөгыльсез калган малайлар Чәрмәсән буена төшеп көн буе шар сукты.* В.Имамов. *Чишмә хезмәтеннән тулып ага Яшәр җирнең елга, инеше. Шар сугасы урам малайлары Хоккей уйный гүзәл сарайда.* В.Галиев; 2) Шар, туп белән уйнала торган уеннарны яки гомумән спорт уеннарын берләштереп, өнәп бетермичә яки шаяртып атау сүзе. *Туп тибәргә, шар сугарга миллиардлар тотыла, ә фәнгә юк.* Р.Вәлиев; 3) Юк-бар белән шөгыльләнү; эшсез йөрү, вакытны бушка уздыру. *Мин монда шар сугып, уйнап йөрмим ләбаса.* М.Яһүдин. **Шар тәгәрәтерлек** 1) Тип-тигез, шоп-шома, тап-такыр. *Таллыклар очына тынлык кунган, су өсте шар тәгәрәтерлек тип-тигез, ник бер шылт иткән тавыш, ник бер хәрәкәт булсын!* Ә.Еники. *Юллар матур, юллар иркен хәзер, Шар тәгәрәтерлек – такырлар.* Г.Латыйп. *Машина тәрәзәсеннән тирә-якны күзәтеп барам. Шар тәгәрәтерлек шома юл. Як-якта җепкә сузылгандай тип-тигез булып яшел куаклар сузыла...* М.Әмирханов; 2) Бөтенләй буш, бернәсә дә булмаган. *Бишме-алтымы тәрәзәсе урамга караган, шар тәгәрәтерлек шыр ялангач бер зур зал иде бу...* Ә.Еники. **Шар тәгәрәтү** Бильярд уйнау. *Аяклар талганчы, күзләр тонганчы бильярд*

*өстәле янында биш-алты сәгать буена шар тәгәрәтү.* Г.Кутуй. *Анда бик яхшы бильярд өстәле бар. Бераз шар тәгәрәтеп алырбыз.* А.Хәсәнов. **Шар тибү** 1) *к.* **шар сугу**. *Атаң буе булгансың инде, шар тибеп җөрер вакытың узган. Бүгеннән башлап тырмага җөрерсең.* Н.Фәттах. *Укып кеше булыр дип уйладым. Булмады. Йөри әнә хәзер шар тибеп...* Х.Ибраһим; 2) *сөйл.* Футбол уйнау

**ШАР** II *кис.* Тулысынча, тәмам, бар мөмкинлегенә. *Капка шар ачык, ләкин ишегалдында җан әсәре күренми.* Ә.Баян. *Кайтса, ишек шар ачык тора.* А.Гыйләҗев. *Бу манзарадан мин тәмам уянам, күзләремне шар ачам.* А.Хәлим

◊ **Шар яру** 1) Һәркем ишетерлек итеп кычкыру, сөйләү, көлү; шәрран яру; 2) Курыкмыйча, яшермичә ачыктан-ачык сөйләп бирү яки ялгышлык белән, уйлап тормастан әйтеп салу. *«Язучы булмыйча, башка һөнәр иясе булырга мөмкин дә түгел иде», – дип, шар ярып әйтеп салганыем бит.* А.Хәсәнов. *Шулай дип, җыелышта шар ярып әйтеп тә бирде.* В.Нуруллин

**ШАРА** *и. сөйл. к.* **шар** (*1–2 мәгъ.*). *Көзен Фәхри шаралы уйный, урамның бер очыннан икенче очына кәшәкә таягы белән агач шара куа.* М.Галәү. *Малайлар кое янында безнең озак маташуны мәзәк иттеләр, өрәңге тубыреннан ясаган шараны юри безнең яккарак тәгәрәттеләр, ачуым килеп, шараны тибеп җибәрим дигән идем, тезем чәнчеште, ыңгырашуымны сизми дә калдым.* А.Гыйләҗев. *Малайларда шара сугу кайгылары китте. Кемузардан таякларын ташламыйча, мәчет ягына йөгерделәр.* З.Зәйнуллин

**ШАРАБАН** *и. фр.* Аркылы агач эскәмияләр рәвешендәге утыргычлары булган, бер яки ике кучәрле ачык агач экипаж; бер кучәрле сиртмәле ачык экипаж. *Чөнки Баскервиль-холл белән ике араны шарабанга утырып барып, Кумб-Тресига таң алдыннан гына җәяү кайтырга туры килгән булыр иде бит аңа.* К.Дойль

**ШАРАБА́НКА** *и. рус к.* **шарабан**. *Аларның кучерлары юк, резина шинлы шарабанкага җигелгән кыскарак буйлы чем кара атны үзләреннән берсе тоткан иде.* Ф.Әмирхан

**ШАРА-БАРА** *и. гади с.* 1) Һәртөрле арзанлы, әһәмиятсез нәрсәләр; гомумән төрле вак-төяк. *Менә нәрсә, бабай, үзең белән бер күлмәк белән ыштан ал да калган шара-бараларыңны ташлап калдыр.* Т.Гыйззәт. *Сул почмакта кечкенә генә, пөхтә генә комодта зур гына көзге, ислемайлар, савытчыклар, хатын-кыз шара-баралары, диварларда әллә ничек кызыл материя берлән ясаган чәчәкләр, алар арасында открыткалар.* Г.Исхакый. *Өйгә кайткач, кәҗәнкәдәге сандыктан, җыен шара-бара арасыннан кечкенә бер капчык алды.* Б.Камалов

2) Абруйсыз, дәрәҗәсез кеше, теләсә кем, ыбыр-чыбыр. *Бу карагруһлар әүвәлдә йөзләп булсалар да, бара-бара берничә шара-бара гына калганга, мөселманнарның йөзенә кара яга алмадылар.* Г.Тукай

3) Буш сүз, кирәксез, әһәмиятсез, вак-төяк, юк-бар нәрсәләр турында сөйләшүләр. *Чынлап та, егетләр, ташлыйк әле шара-бараны.* М.Әмир. *Ризык чемченеп, шара-бара сөйләшеп тордык та, баягы капканы йокысыннан уятып, шыгырдатып ачып урман якка чыктык.* А.Гыйләҗев

**2.** *с. мәгъ.* Түбән дәрәҗәдәге, килделе-киттеле, ни җитте шундый

**3.** *рәв. мәгъ.* Аннан-моннан гына, теләр-теләмәс, җиренә җиткермичә. *Өйдә чакта шара-бара гына сөйләшеп утырганнар иде, урамга чыккач та, Мәүлия сүзчәнләнеп китте.* Я.Зәнкиев

**ШАРА́ГА** *и. рус сөйл.* 1) Сталин репрессияләре чорында төрмә тибындагы ябык фәнни тикшеренү үзәге, конструкторлар бюросы һ.б.ш. учреждение

2) Жуликлар оештырган берәр эш, чара; шикле, ышанычсыз компания. *Вак кибетләрне шарагалардан сакларга алыныр иде – беләк нечкә, йодрык бәләкәй. Алыпсатарлыкка китәр иде – хәйләсе юк ---.* Р.Батулла

3) Кирәксез, вак-төяк һ.б.ш. эш белән шөгыльләнә торган оешма яки учреждение. *Акча бер хәл, җаным, квартир кирәк. Заводта эшләмәсәң, аны каян аласың? Тәлгатьнең шарагасындамы? Шиш!..* Ә.Дусайлы

**ШАРА́ДА** *и. фр.* 1) Табышмакның бер сүзне берничә мөстәкыйль сүзгә бүлеп, җавабын табу өчен аларның һәрберсен аерым уйлап табып, бергә берләштерергә кирәк булган төре (мәс.: бал-чык). *Болар – уку-язуга, сүзләрнең күп мәгънәлелегенә һәм башка күренешләргә нигезләнгән шарада, метаграммалар.* Д.Абдуллина. *Шарада нинди дә булса сүзнең иҗекләре аңлаткан мәгънәләрне әйтеп, шул сүзнең үзен табуны сорый. Мәсәлән, «Беренче кисәге – сыеклык, икенче кисәге – Татарстандагы елга, кушып укысаң – табигать күренеше». Җавап: суык (су – Ык).* Ай колакланса, ни була?

2) *күч.* Буталчык, аңлашылмаган хәл, күренеш яки читләтеп әйтелгән сүз. *Талантлы замандаш шагыйрьләренә хас булганча, кайвакыт катлаулы метафоралар белән эш итсә дә, аның язганнары аңлашыла, беркем чишә алмаслык, ә бәлки кайвакыт чынлыкта да мәгънәсе булмаган шарада рәвешен алмый.* Р.Рахман

**ШАРА́ЖКА** *и. рус к.* **шарага**. *Гомумән, ни пычагыма дип шул Тәлгать бушбугазга тагылды соң әле ул? Нәрсә дип шул шаражкага барып керде?* Ә.Дусайлы

**ШАРАЙТУ** *ф. сөйл. к.* **шарландыру** (*2 мәгъ.*). *Кесәсендә шырпы юанлыгында гына диярлек «Ракета» папиросы булган баягы студент күзләрен шарайтып катып кала – соң, килеше-килбәте белән язучыга бөтенләй дә охшамаган бу кеше күптән түгел генә аңардан тартырга папирус сораган иде ләбаса!* М.Хуҗин. *Моны ишеткәч, минем аркага әлеге кайнар чәйне койган кебек булдылар, мин, күземне шарайтып, Иван Павловичка карадым.* Т.Нурмөхәммәтов

**ШАРАЛЫ** *и. сөйл. к.* **шарлы 2.** *Малай бу шар белән чукмарын алып урамга чыга да иптәшләре белән шаралы уйныйлар.* Әкият. *Шаралы, чебенле уйнап, Эстәрле суында кәрҗин белән ташбаш, маймыч, этем балыклары тотканнар.* З.Зәйнуллин. *Ул уен шаралы дип атала.* Татарстан яшьләре

**ШАРА́ШКА** *и. рус к.* **шарага**. *Эстрадабыз – Шарашка, Җырларыбыз – Шабашка!* Р.Миңнуллин. *Садыйк: – Китәм мин бу шарашка конторасыннан, – дип сукранды.* Р.Кәрами

**ШАРА́ШКАЧЫ** *и.* Шарашкада эшләүче кеше. *Королёв, – әлбәттә, мәҗбүри шарашкачы, ә фон Браун фашист режимына үзе теләп яллана, ләкин балачак хыялы хакына, кешелек дөньясына космик канатлар үстерү хакына...* А.Тимергалин

**ШАРАЮ** *ф. к.* **шарлану**. *Яшь кыз күргәч, күзләре шарайды абыем җанымның...* М.Хуҗин. *Эчкәнем юк, эчә алмыйм, дидем. Гали абыйның болай да зур күзләре шараеп, ат күзенә әйләнде.* Б.Камалов

**Шараеп калу** Шарайган хәлгә килеп, шул рәвешен саклау. *Әйе, әйе, шакмакландырма бәбәгеңне, калдырдым да*

*киттем, күзләре шараеп кына калды.* Г.Каюмов

**ШАРЖ** *и. фр.* 1) Кайбер типик үзенчәлекләрен чынбарлыктагыдан күпертебрәк, алгы планга чыгарыбрак, шаяртып яки сатирага тотып ясалган рәсем, гадәттә портрет. *Шуның өстенә, ул рәсемгә дә оста малай булып чыкты: журналга әллә нихәтле юмористик шаржлар ясап, фоторәсемнәр төшереп җибәрә һәм аларның байтагысы журналда урын да ала иде.* Ш.Маннур. --- *«Тынгысыз каләм» эленеп тора. Анда язучыларның көлкеле шаржларын күреп, бер-берсенә карата язылган төртмәле шигырьләрен укып, рәхәтләнеп шаркылдашып көлеп торырга була.* Л.Хәмидуллин

2) Кемне яки нәрсәне дә булса шундый юмористик яки сатирик планда тасвирлау алымы. *Әсәргә концепция бөтенлеге, сюжет тыгызлыгы җитми. Аның аерым өлешләре фаҗига, шарж, сатира алымында язылган, төрле-төрле физик һәм химик катнашма рәвешендә калган, роман буеннан-буена бердәй составлы тоташ эремә хәлендә килеп җитмәгән.* Т.Әйди

3) Кемне яки нәрсәне дә булса кабатларга тырышкан, ләкин тиешле дәрәҗәдә булмаган, эшкә яраксыз нәрсә. *Кайбер талантлы артистларыбыз чит ил классикасын менә дигән итеп башкаралар, ә үзебезнең көйләрне шарж, пародия кебегрәк тамак төбе белән җырлыйлар.* Ф.Хатипов

**ШАРЖЛАНДЫРУ** *ф.* Шаржга охшату, шарж рәвеше бирү // Җитдилеген, әһәмиятен киметү. *Сез, Заһид Сафич, артык шаржландырасыз. Сүз бит хезмәтнең практик әһәмияте турында бара.* А.Расих

**ШАР-ЗОНД** *и. рус* Атмосфераны өйрәнү өчен һавага җибәрелә торган, водород яки гелий тутырылган резин яки пластик сүрүдән һәм шуңа асылган аппаратура контейнерыннан гыйбарәт пилотсыз аэростат. *Сулдан, биек-биек, үтә күренүчән ангарлар ягыннан, шар-зонд очып чыкты да яңгырларын коеп җиңеләеп калган күгелҗем-аксыл болытлар янына тирбәлә-тирбәлә менеп китте.* А.Гыйләҗев. *Чара яшь техниклар станциясендә тәрбияләнүчеләр ясаган самолёт модельләрен, һава еланнарын һәм бәйрәмнең төп символы – стратосферага зур шар-зонд җибәрү белән тәмамланды.* Әлмәт таңнары

**ША́РИК** *и.* рус 1) Кечкенә шар, шарчык; шундый формадагы берәр нәрсә. *Алар чәчләрен тасма белән үреп, ак бантиклар белән бизәгәндә, Гүзәлнең толым очларына моңарчы Сукмаклы Тау кибетендә күренмәгән пластмасс шариклар, алтынсу күбәләкләр, тагын әллә нинди нәрсәләр куела торган иде.* Р.Рахман. --- *автогиганттан күбрәк файда алу һәм аның тәэминатчыарадашчыларга бәйлелеген бетерү өчен, КамАЗның үз металлургия базасын, шарикль подшипниклар һәм электр техника заводларын салу кирәк.* В.Шәрипов

2) *күч.* Акыл, аң, акыллылык дәрәҗәсе, уйлау, фикер йөртү сәләте. *Бәлки, чыннан да шулайдыр, мәктәптә җиде ел буена кермәгәнне тутыга башлаган шарикларга сугыш җиде көндә сеңдерә торгандыр.* Н.Әхмәдиев. *Әллә нинди акыллы уйлар килә төнлә. Көндез баш эшләми. Төнлә баштагы шарикларны чистартып куялармы? Кайвакыт шулай айлы төндә барасың айга каршы, нинди генә уйлар килми.* Т.Миңнуллин

◊ **Шаригы бушау** Акылына зыян килү, фикерләү сәләте зәгыйфьләнү. **Шаригы какшау** *к.* **шаригы бушау**. – *Нәрсә сөйлисең син? – диде ул аптыраулы тонык тавыш белән, – әллә теге ни... ми шарикларың какшый башладымы?* А.Вергазов

**ШАРИКЛЫ** *с.* Эшләү принцибы шарик куллануга нигезләнгән, төп детале шарик булган. *Бу – шариклы мина. Шартлаганда, бака кебек югарыга таба сикерә, шариклары чәчелеп китә, бил тиңентен биеклектәге бөтен нәрсәне кыя.* Х.Камалов. *Ирек, алгы өйгә чыгып, пинжәк кесәсеннән берничә төсле кара белән яза торган шариклы каләмен алды.* Г.Рәхим

**ШАРИКОПОДШИ́ПНИК** *и. рус* Подшипникның шарчыклар ярдәмендә эшли торган төре. --- *Мәскәүнең шарикоподшипник заводын салучылар сменага – 600, ә Харьков трактор заводы төзелешендә 800 измә биргәннәр.* Казан утлары

**ШАРКҮЗ** и. Бик зур күзле кеше; акайган күзле кеше. *Син нәрсә, шаркүз, атлар саклыйсы урында кызлар янына чаба башладыңмыни?* Г.Әпсәләмов

**ШАРКЫЛДА́У** *ф.* Гөрләтеп, яңгыратып, кычкырып көлү. *Мансур мондый нахак сүзләрдән соң тәмам телен йотты, Шамил үрәчә өстендә сикергәлисикергәли шаркылдады.* В.Имамов. *– Ха-ха, – дип, йөгәнсезләнеп шаркылдады тегесе, – безгә патшадан кала барча юлчыларны да тикшерү хокукы бирелгән, беләсездер, шәт, күктән төшмәгәнсездер.* М.Әмирханов

**Шаркылдап алу** Бераз шаркылдау. *Җәмил, шушы яшькә кадәр нindидер могҗиза белән сакланган тешләрен күрсәтеп, бер шаркылдап алды, аннары җитдиләнеп сорап куйды ---.* И.Шиһапов. *– Килештек, – дип, Гөргөри үзенә генә хас ямьсез матур көлү белән шаркылдап алды.* Р.Зәйдулла

**Шаркылдап җибәрү** Кинәт шаркылдый башлау. *Әнисенең калтыранган кулларын күреп, Луиза чак кына шаркылдап җибәрмәде.* А.Гыйләҗев. *– Бик ансат икән! – дип, дивана бәндәдәй шаркылдап җибәрүемә Мирзаның күзе тонды, теле томлыкты.* Ф.Баттал

**Шаркылдап йөрү** Гел, һаман шаркылдау. *Хәйдәр безнең арада һаман көлеп шаркылдап йөри.* Ә.Еники. *Яшьләр күп, әмма бездәге шикелле, кулларына сыра шешәсе тотып, тәмәке суырып, тиләрчә акырып, шаркылдап йөрүче бер генә егетне яки кызны да очратмадык ---.* Туган як

**Шаркылдап кую** Кинәт шаркылдау; бер мәртәбә, кыска гына шаркылдау. *Аның сурәтләре янныннан шаркылдап куймыйча, эчен тотып көлмичә берәү дә уза алмый.* А.Хәсәнов. *Чыдый алмыйча шаркылдап куйдым, Дамир сизенә, төс аермый торган күзләрен акайтып, миңа карады ---.* А.Гыйләҗев

**Шаркылдап тору** Билгеле вакыт дәвамында шаркылдау; хәзерге моментта шаркылдау. *Минем сорауны бөтенләй ишетмәгәндәй, ул тагын берәр минут чамасы шулай шаркылдап торды.* В.Нуруллин. *Ә монда, җитмәсә, тешләрен ыржайтып, «купич» дип шаркылдап торалар!* И.Диндаров

**Шаркылдый башлау** Шаркылдарга тотыну. *Шуны гына көткән диярсең, бөтен класс миңа кушылып шаркылдый башлады.* И.Диндаров. *Хатын бераздан шаркылдый ук башлады.* Г.Әдһәмова

**ШАРКЫЛДАШУ** *ф. урт. юн. к.* **шаркылдау**. *Тотыш, айгыр кебек кешнәгән, шаркылдашкан гарәпләргә катнашмыйча аптырап, тынын кысып, бер читтәрәк басып торды.* Н.Фәттах. *Малайлар үз-үзләреннән канәгать булып шаркылдашалар, мине үчекләп төрткәлиләр.* И.Диндаров

**Шаркылдашып алу** Бераз шаркылдашу. *Барыбыз да шаркылдашып, тормәне яңгыратып алдык.* И.Туктаров

**Шаркылдашып тору** Билгеле вакыт дәвамында яки хәзерге моментта шаркылдашу

**ШАРКЫЛДЫК** *с.* **1.** 1) Артык шаулап, шаркылдап көлү гадәте булган, кычкырып көлүчән; гел көлеп кенә торган. *Әллә нихәтле вакыт узды, шаян егетләрнең дә авызы ябылды, шаркылдык кызлар да телен тешләде.* Р.Камал

2) Артык сөйләмчәк, күп һәм кычкырып сөйләү гадәте булган

3) Җиңел холыклы, бер нәрсәне дә җитди кабул итмәгән. *Беләсең аның шаркылдык ярты акыл җиңгәсен: мине күрүгә, шул ахылдап килеп чыкты.* Г.Ибраһимов

**2.** *и. мәгъ.* Шундый гадәтле кеше. *Озын толым бу шаркылдык белән нинәрсә турында сөйләшә икән?* Н.Гыйматдинова

**ШАРЛАВЫК** *и.* 1) Гадәттә, ташлы җирдән шаулап ага торган кызу агымлы, ләкин сай су; инеш. *Ул төштә инеш кыш уртасынача катмый бит, юл була ич ул төштә. Шарлавык бит анда, чана төбенә җитми ич анда су.* М.Хуҗин. *Җаным буйлап сагыш сызамы?.. Үткәннәрдән кайта йөрәк шавы, Шарлавыклар булып ага моң...* Л.Шәех

2) Гөрләвек. *Шарлавыклар гөрләшеп актылар да каядыр, җир астына төшеп югалдылар.* Н.Дәүли. *Буран артыннан ук кар ашыгып эри башлады, бөтен ерганаклардан, кырлар өстен тонык гөрләтеп, шарлавыклар йөгерде.* Ә.Еники

3) Агымның ташлы җире; су юлында өелеп калган, судан чыгып торган ташлык. *Инеш аны ташлы шарлавыкка чыгарды. «Ничек батып үлмәдем икән?» – дип уйлады ул.* Ф.Яхин

4) *к.* **шарлама**. *Шарлавыкларны гидроэлектростанцияләр төзү өчен файдаланырга мөмкин. Шундыйлар рәтеннән Ниагара (биеклеге 51 м, киңлеге 1100 м, АКШ), Игуасу (биеклеге 72 м, киңлеге 4000 м, Бразилия), Виктория (биеклеге 140 м, киңлеге 1800 м, Көньяк Африка) шарлавыкларын атарга мөмкин.* К.Гыйззәтов

5) Гомумән көчле агым. *Ул кухнядагы кайнар су кранын бар куәтенә җибәрде дә өстәлдәге бушаган савыт-сабаларны шул шарлавык астына куйды.* К.Тимбикова

**ШАРЛАВЫКЛАНУ** *ф.* Агым көчәеп китеп шарлавыкка әйләнү, шарлавык рәвешен алу. *Су агышы аның кулындагы термосны тартып алып, өч сәгатьтән бирле шарлавыкланып казылган чоңгылга томырды.* К.Кәримов

**ШАРЛАВЫКЛЫ** *с.* Шарлавыклары (*1 мәгъ.*) булган, шарлавыклар хасил иткән. *Текә ярларыннан ничекләр төшәсең дә шарлавыклы сулары өстеннән салынган караңгы тайгак күперләрдән ни рәвешле имин чыгасың?* Ф.Яхин. --- *Акташта машиналарга бензин-солярка өстәп, Бута авылының шарлавыклы чишмәсеннән сулар эчкәч, Әлмәт, Чистай, Алексеевск районнарының юл өстендә аунап яткан авылларын үтеп, --- бара торгач, ниһаять, Чулман елгасының ин киң җиренә – «Саескан тавы» кичүенә килеп җителгән.* К.Кәримов // Шарлавыклар (*3 мәгъ.*) аша уза торган

**ШАРЛАВЫКСЫЗ** *с.* **1.** Шарлавыклары булмаган

**2.** *рәв. мәгъ.* Шауламыйча, шарлавыклар барлыкка китермичә. *Ә гаҗәеп елга ага да ага... Шарлавыксыз, тын гына ага.* С.Сөләйманова

**ШАРЛАМА** *и.* 1) Су агымының биеклектән ургылып төшкән ташкыны; *русчасы:* **водопад**. *Алар ишелергә торган кыя төбеннән, тарлавыклардан, судан яртылаш кына чыгып торган ташларга сикерә-сикерә үтеп, коточкыч бер көч белән коелып торган шарлама янындагы тау тишегенә килеп керделәр.* Г.Әпсәләмов. *Таулар күкрәгеннән чишмәләр бәреп чыккан. Аларның күбесе, шарлама ясап котырып-котырып, түбәнгә ташлана.* Ф.Яруллин

2) Гомумән көчле агым, ташкын; агымның шундый урыны

3) *к.* **шарлавык** (*1 мәгъ.*). *Авылның түбән башындагы шарламага төшәсе калган икән, анда карыш буе ташбашларны чүпләп кенә торасың хет.* М.Хуҗин

4) *к.* **шарлавык** (*3 мәгъ.*). *Шаулап-ыргып аккан су өстенә аркылы-торкылы агачлар ауган. Бәлки, шуңадыр елга күбекләнеп, әллә нинди шарламалар ясап, чоңгылланып ага.* М.Хәсәнов

5) *к.* **шарлавык** (*2 мәгъ.*). *Ул мине үз янына чакырып ишарәләде. Тар шарламаны сикереп чыктым да аның янына барып чүгәләдем.* М.Хуҗин

6) Буа, электростанция һ.б.ш. гидротехник корылмаларда су басымын киметү өчен артык суны агызу җайланмасы; *русчасы:* **водосброс, каскад**. *Буалар шарламасының дүртенче баскычын төзи башлагач, Шәфәгать Тәхаутдинов, Германиянең көньяк-көнбатышында урнашкан Баден-Баден каласының ландшафт архитектурасы үрнәкләре белән танышып, алар тәҗрибәсен үзебездә кулланырга, дигән әмер бирә.* Шәһри Казан

7) Бина эчендә яки ачык һавада, ешрак җәмәгать урыннарында, матурлык, дәвалау һ.б.ш. максатларда каскад, чишмә рәвешендә эшләнгән ясалма су агымы. *Яңадан салкынча минераль су белән бассейн керү, өстән аккан шарлама астында утырулар, тәмле төшке аш, кайнар минераль сулы бассейн, джакузилар – төштә кебек кенә истә калган.* Сәхнә

8) Ишелеп, коелып торган берәр нәрсәнең мул, көчле агымы. *Ул бодай шарламасы астына кереп баса. Бер генә мизгелгә бодайдан коеп куйган җиз сын булып кала.* Ә.Гаффар

9) *күч.* Агым, ташкын рәвешендә бертуктаусыз, өзлексез дәвам иткән процесс. *Әйтче, язмыш, Уйлар шарламасы ага, Ярдан түбән атылып. Әйтче, язмыш, бармы тагын Уаласым ватылып?* Э.Шәрифуллина

10) *күч.* Кискен борылыш, тамырдан үзгәреш; ыргым. *Хәер, баш әйләндергеч сикерешләре, шарламалары очрамаса, сай сулы елга шикелле талгын гына агып ятса, мәзәге белән рәхәте дә булмас иде тормышның, йөрәкләр мүкләнеп бетәр иде.* Г.Мөхәммәтшин. *[Тормыш] агымын көчәйтә, я акрынаеп тора да, шарлама ясап, кинәт түбәнгә ургыла.* А.Гыйләҗев

**ШАРЛАМАК** *и. сир. к.* **шарлавык**. *Бары тик сайрак урыннарда, агым көчле булган шарламакларда гына бу яктылык ватыла, су өсте шадралана, челпәрәмә килгән көзге кисәкләренә охшап, көмеш тәңкәләр хасил булалар.* М.Хәсәнов. *Бүә ул бер урында салмак, тыныч ага, ярлары куркыныч, яшькелт суы тирән. Икенче бер урында ул югарыдан төшкән шарламак сыман шаулап, тавышланып ага.* Н.Фәттах

**ШАРЛАМАЛАНУ** *ф.* Ургып, томырылып, кызу агым белән агу; ургылу, шарлама рәвешен алу. *Текә ярга килеп бәреләә, кайда сайлыкта салмаклана, кайда эре ташлар өстеннән шарламаланып ага, ләкин аңа карап суы болганмый, саф килеш кала.* Өмет

**ШАРЛАМАЛА́У** *ф.* 1) *к.* **шарламалану**. *Әгәр ул шарламалап акмаса, көймә йөзәрлек булса бик шәп инде.* З.Мурсиев

2) Көчле агым белән агызу. *Әйтеп, исеңә төшерәм алайса: теге елны, чәнчеп, канымны шарламалап агызган идеңме?!* М.Шаһимәрдәнов

**ШАРЛАМАЛЫ** *с.* Шарламалары булган, шарламалар хасил иткән; шарлама рәвешендәге. *Сөембикә сөйләгәндә, Сандугачлар сокланган. Шарламалы елга хәтта Агышыннан тукталган.* Э.Шәрифуллина. *Аннары паркның итәгенә – Казан елгасы буена төшеп, урап бардык-бардык та, Кремльгә җитәрәк хәрабә калдыклары, субайлары әле дә калкып торган иске тегермәннең шарламалы буасында су коендык.* Т.Нурмөхәммәтов

**ШАРЛАНДЫРУ** *ф.* 1) Шар формасына кертү, шар рәвеше бирү

2) Зур итеп ачу, акайту, шар кебек итү (күзләр тур.). *Шәмсеруй да, ишегалдын айкаган бүре малаен күреп, әчтерхан чикләвегедәй зур күзләрен тагын да шарландырган.* А.Хәсәнов. *Фәрит, күзләрен шарландырып, озак итеп миңа карап торды, үзе дә сизмичә сызгырып җибәрде.* И.Диндаров

**Шарландырып тору** Шарландырган хәлдә булу. – *Ә син, мәхлук, нәрсә бәбәкләреңне шарландырып торасың?* И.Салахов. *Ул әллә сугарга ниятләде, әллә төртеп егарга, бәбәкләрен шарландырып текәлеп торды да ишеккә ташланды ---.* А.Гыйләҗев

**Шарландырып утыру** *сөйл. к.* **шарландырып тору**. *Бу юлы алар, мунчаның аргы башында күзләрен шарландырып утырган баканы күреп, бик чыр-чу килешкәннәр иде.* А.Хәсәнов

**ШАРЛАНУ** *ф.* 1) Шар формасын алу, шар рәвешенә керү. *Яктысы бүлек-бүлек булып шарланып, бер ачылып, бер йомылып, безнең аяк асларыбызда тәгәрәп, уйнаклап йөри иде.* Ф.Әмирхан

2) Зур булып ачылу, акаю. *Аның зур коңгырт күзләре шарланган, ялтйолт килә, ләкин ни өчен шулай икәнен аңлавы кыен иде.* В.Нуруллин. *Әниеңнең күзләре шарланды: тәмам исе-акылы китте. Әйе, ничек инде аның бердәнбер улы ниндидер кыргый Атилла хан кызына өйләнсен ди?!* М.Хәбибуллин

**Шарлана бару** Торган саен ныграк шарлану

**Шарлана башлау** Шарланырга тотыну

**Шарлана төшү** Бераз шарлану; тагын да ныграк шарлану

**Шарланып калу** Берәр сәбәп белән шарланган хәлгә килү. *Хәтта гадәттә чылт-чылт йомылып торган күзләре дә шарланып туктап калганнар.* И.Салахов

**Шарланып китү** Кисәк шарлану, сизелерлек дәрәҗәдә, шактый нык шарлану. Моны [көн тәртибен] *күргәч, Ибраһимның күзләре шарланып китә.* Г.Гобәй

**Шарланып чыгу** Бөтенләй шарлану, бик нык шарлану. *Баян колакларын тырпайтты, күзләре шарланып чыкты.* В.Имамов

**ШАРЛАТАН** *и. фр.* **1.** Белеме, махсус әзерлеге булмый торып, берәр эшкә керешүче кеше, надан. --- *табиблар, бер дә каушап калмыйча, бер кешенең йөрәген икенче затка күчереп куя башладылар. Шул ук вакытта төрле шарлатаннар алдында баш иябез, соңгы тиеннәребезне түләп, аларның сеансларына йөрибез.* А.Хәсәнов. *Берничә яңа сүз ятлаган бу шарлатан митингларда туктаусыз чыгыш ясый, нәрсә сөйләгәнен дә юньләп белмичә, эшче-крестьяннарга өстенлекләр таләп итә.* А.Әхмәдуллин // Файда алу өчен үзен белгеч итеп күрсәтергә тырышучы кеше; аферист, алдакчы. *Мин дә заманында күп йөрдем врачларга. --- Берсе бер дару язып бирә, икенчесе икенче дару, Халтурщиклар! Шарлатаннар!* Н.Фәттах

**2.** *с. мәгъ.* Чын белгеч булмаган, ялган, надан. *Юк, юк, синең шикелле шарлатан хәлфәләр укыган никахны мин танымыйм!* Т.Гыйззәт. *Үтә чыккан ахмак, шарлатан кеше!* Ф.Яхин

**ШАРЛАТАНЛАНУ** *ф.* Шарлатанга әверелү, шарлатан булып китү // шарлатанлык белән шөгыльләнү. *Мәгәр театрлар белән махсус драматерапия сеанслары уздыра алсагыз, монысы халыкны алдау да, шарлатанлану да булмас иде.* Сәхнә

**ШАРЛАТАНЛЫК** *и.* Үз эшен белмәү, белемсезлек, наданлык. *Көндәшләре карт астрономнан планетаны таптыра башлыйлар. Аны хәтта шарлатанлыкта гаеплиләр. Галлей агай үлеп китә.* А.Хәсәнов // Ялганчылык, алдакчылык. *Кыскасы, җитди галимнәр һәм мәдәни халыклар астрологияне «ялган фән» («псевдофән») һәм шарлатанлык дип саный башлаганнар.* А.Тимергалин. *Татар матбугатында кайбер галимнәребезнең «Төркиядә елына йөз мең исемдә китап басыла» дип язуларын исә шарлатанлык дип кенә бәяләргә кирәк!* Т.Әйди

**ШАРЛАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн.* **шарлау**

2) Көчле агым белән, мул итеп агызу, түгү. *Эчтә савыт-саба шалтырады, шарлатып су агыздылар. Күрәсең, алар кухняда иде.* Ф.Садриев

**ШАРЛÁУ** *ф.* 1) Су яки башка сыеклык көчле агым белән акканда тавышлану, шаулау, гөжләү. *Авыл уртасындагы инештән шарлап аккан ташу тавышына кемнеңдер ачы авазы кушылды: – Ярдәм итегез!* М.Мәһдиев. *Беренче март көне килде, һава җылы, гөрләвекләр шарлый, тамчылар тама, кояш кышкы йокыдан сулыккан битләрне иркәли, тәнгә тормыш, яшәү дәрте сеңдерә.* Т.Галиуллин

2) Көчле агым белән агу, ургып, гөжләп агу. *Арада Шивилгән үзәк урамыннан шарлап, ташкынланып агып төшкән сае – елгачыгы белән, күкрәп, бертоташтан үсеп киткән йөзем-җимеш бакчалары белән дан тота иде.* Ә.Мохтар. *Борыныннан шарлап кан китте.* Т.Галиуллин. *Елганың суы саф, ул шарлап ага, хәтта төбендәге зур-зур ташларга хәтле ап-ачык булып күренеп тора.* Ф.Бәйрәмова

**Шарлап тору** Гел шарлау; әле хәзер шарлау

**Шарлап яту** *сөйл. к.* **шарлап тору**. *Бер төн эчендә шарлап яткан елга аша күпер салып, иртән танкларны үткәрә торган идек.* Т.Гарипова

**Шарлый башлау** Шарларга тотыну

**ШАРЛАХ** *и. нем.* Тимер оксиды нигезендә ясала, йон һәм ефәк буяу өчен кулланыла, төсенең матурлыгы һәм җетелеге белән аерыла торган ачык кызыл, көрәнсу төстәге буяуларның гомуми атамасы. *Шарлах кояшта тиз уңа*

**ШАРЛÓТКА** *и. фр.* Камырга күп итеп алма кушып әзерләнгән татлы ризык. *Пешеп чыккан шарлотканы мичтән алгач, шунда ук кисмә, ул бераз суынсын.* Матур буласың килсә. *Үзегезне дә, башкаларны да гади, кечкенә бүләккә иәләндерегез, өч йомырка, берәр стакан он һәм шикәрдән үзең пешергән шарлотка кыстырып барсаң, шул җиткән!* Татарстан яшьләре

**ШАРЛЫ** *с.* **1.** 1) Шары, шарлары булган, шарлар куелган, шар белән бизәлгән. *Кичен кино, ял көннәрендә офицерлар йортында биюләр, ак шарлы бильярд өстәле.* М.Мәһдиев. *Алдан ук көн эсселегенә сылтап, ялтыр шарлы караватын җир идәнле келәтләренә күчертте, тышта һава салкынрак, янәсе.* К.Кара

2) Шар формасындагы, шар итеп эшләнгән. *Күз алдында хәтта шарлы яшеннәр дә пәйда булгалады.* Ә.Гаффар

3) Төп өлеше, төп детале шар булган, эшләве шуңа нигезләнгән. *Биредәге Е-2 линиясенең шарлы клапаннары аша чыккан материал Т-2 суыткычының*

*дефлекторизация секторында вакуум ярдәмендә икенчел басымга дучар ителә һәм Ш-2 трансформаторыннан чыккан электр дугасы ярдәмендә зур диаметрлы көпшәгә юнәлдерелә.* Җ.Юнысов. *Соңыннан цемент клинкеры шарлы тегермәндә гипс өстәп тарттырыла, онга әйләндерелә.* Төзү материаллары. *Шарлы подшипник*

**2.** *и. мәгъ.* Кечкенә туп, шар кебек йомры нәрсәне кәшәкә таяк белән сугып яки башкача уйнала торган уен. *– Алпар кая? – Урамда. Урам малайлары белән шарлы уйный.* М.Хәбибуллин

**ШАРМ** I *и. фар. иск.* Оят. *Раббым, явызларның шармыннан сакла, рухым сүндермә! Асыл максатка җитмәчә, тәнемне җиргә күмдермә!* А.Җәгъфәр

**ШАРМ** II *и. фр.* 1) Кешенең башкаларны җәлеп итү үзенчәлеге, үзенә күрә бер мөлаемлык, сөйкемлелек. *Хәзер мин кистереп әйтә алам, анда үзенә тартып торган ниндидер серлелек, заманча әйтсәк, шарм бар иде.* Р.Габделхакова. *Шулай да бер югары нотада тавыш калтыранып китә. Бу аңа кабатланмас шарм өсти.* М.Әмирханов

2) *күч.* Бизәнү әйберенә тагыла, ешрак чылбыр, беләзек кебекләргә кидерелә торган ювелир төймә

**ШАРМА́НКА** *и. рус* Берничә гади генә көй уйнарга көйләнгән, җилкәгә асып йөртерлек зурлыктагы тартма рәвешендә клавишсыз, кулдан әйләндереп уйнатыла торган механик орган. *Төрле видео, магнитофон, патефоннарга караганда, музыканы гади авазларга таркатып бетерә торган шарманканы ярата төшә иде ул...* А.Тимергалин. *Шарманканың уйнавын тыңлап, ул сихерләнгән кебек була, көне буе шарманкачы янында бөтерелә.* Р.Батулла

2) *күч. ирон.* Берәр ошамаган, матур, җитди, кирәкле дип саналмаган уен коралы. *Юк шул, бездә әнә шарманка уйнаучы, туп тибүче бер легионер сатып алыр өчен дә дистәләрчә миллион евро туздыралар, әмма инде кеше исәнлеге өчен бер тиен дә тотылырга тиеш түгел.* Безнең гәҗит

3) *күч. ирон.* Түбән сыйфатлы булганга яки башка сәбәпләр белән тыңлаучыга ошамаган радио, магнитофон һ.б.ш. музыка уйнату җиһазы. *Барысы да, Җәмилә әйтмешли, синтезатор шарманкасына кычкыра.* Ватаным Татарстан

4) *күч.* Ялыктыргыч, эчпошыргыч, бер үк төрле сүз. *Сабакташ алай тиз генә лаеклы ялга чыга алмас, ахры әле, әнә Россия Финанс министрлыгы кабат пенсия шарманкасын әйләндерә башлады, һәм ул бер дә пенсионерлар файдасына түгел.* Шәһри Казан

**ШАРМА́НКАЧЫ** *и.* Шарманкада уйнаучы кеше. *Ул язмыш, ул фаҗига Әдрән диңгезе ярларыннан Русиягә бер шарманкачыга ияреп килгән әнисенең әнисенә – әбисенә бәйле.* К.Латыйп. *Мондый театр шарманкачы яки скрипкачыдан, берничә курчактан, курчакчының үзеннән торган.* Кызыл таң

**ШАРМА́НЩИК** *и. рус* 1) к. **шарманкачы**. *Хәзер, элеккеге шарманщиктан – сюжетка махсус кертелгән персонаждан аермалы буларак, алып баручы башка функцияләрне башкара: сәхнә образы булып тора ---.* Н.Игъламов

2) *күч. мыск.* Берәр музыка коралында аннан-моннан уйнаучы яки аппаратура ярдәмендә түбән сыйфатлы музыка уйнатучы кеше. *Син әллә анда, кыямәттән соң беренче көнне үк дискотека оештырырлар дип уйлыйсыңмы?! Күземә күрсәтмә шул шарманщикларыңны!* К.Кәримов // Сәләтсез җырчы. *Теге шизик кыяфәтле Тимати дигән шарманщик та безнең нәселдән бугай, чын исеме – Тимур.* Ватаным Татарстан

**ШАРНИР** *и. фр.* Ике өлеше дә уртак күчәр яки уртак үзәк тирәсендә әйләнерлек итеп тоташкан кинематик пардан гыйбарәт җайланма; тупса. *Чик шартларын билгеләгәндә, аскы казна шарнирга таянган дип алыныа.* Фән һәм тел. *Капка, ишекләр (хәтта баз ишеге дә!) – барысы да ачыла, чөнки шарнирга беркетелгән.* Әгерҗе хәбәрләре

**ШАРНИРЛЫ** *с.* Шарниры булган, шарнир принцибында эшли торган; тупсалы. *Камераны мониторга да тоташтырып була ич! --- Бик теләгәндә аны шарнирлы җайланмага урнаштырып, «муенын» уңга-сулга бора торган итәргә дә була.* А.Гыймадиев. *Планёрка вакытында шарнирлы күн тәхетеннән төшеп, коллектив арасындагы агач аяклы урындыкка күчеп утыруы да гадәттәгечә гадилек уены гына.* К.Кәримов

**ШАРОВАР** *и. фар.* Билен һәм балак очларын бөреп, юка материядән тегелгән озын киң чалбар. *Егетләр барысы да диярлек чигүле украин күлмәгеннән, шароварларының киң балаклары каптыра ялтыраткан күн итек балтырларына салынып тора.* Җ.Рәхимов. *Малай өстенә шаровар киеп куйды, җилкәсенә ниндидер юка телогрейка шикелле киемне салды.* Р.Гаязетдин

**ШАРОВАРЛЫ** *с.* Шаровар кигән. *Менә эскерт өстендә печән тигезләүче шароварлы кызлар түбәнгә шуып төшәләр һәм егетләр кулына барып керәләр.* Х.Камалов

**ШАРО́ВКА** *и. а.х.* Шаровкалау эше, шуның процессы һәм нәтиҗәсе

**ШАРО́ВКАЛАУ** *ф. а.х.* Туфракта дымны саклау, чүп үләннәрен бетерү максаты белән рәт араларын йомшарту, чәчүдән соң беренче эшкәртү, сай итеп йомшарту. *Трактор белән шаровкалаганнан соң, плантация матурланып, үсемлекләр күрәеп китте.* Казан утлары

**ШАРО́ШКА** *и. рус* 1) Станок, электр дрель кебекләргә беркетеп, каты өслекләрне кыру, шомарту һ.б.ш. өчен кулланылган, үтә каты тешләре булган яки тоташ абразивтан торган, гадәттә, конуссыман формадагы фреза рәвешендәге слесарьлык коралы. *Вольфрам шарошка. Металл өслек өчен шарошка*

2) Җир бораулаганда каты токымны механик рәвештә бәреп вату, кыеп төшерү, ваклау өчен каты металлдан ясалган тешле геологик җиһаз төре. *Ике шарошкасы кырылып төшкән. Тартакиев лом алды да бүтән шарошкаларны да ватты. Юкса ремонтка алмыйлар, шуның белән эшләргә кушалар.* Х.Камалов. *Икәүләп бик озак карадылар борауны, шарошкаларын селкеттеләр, тешләрен капшадылар. Башкалардан аермасы юк.* Ф.Мостафин

**ШАРО́ШКАЛЫ** *с.* Шарошка белән җиһазландырылган, шарошка ярдәмендә эшли торган. *Көнчыгыш районнарда исә, гадәттә, шарошкалы бораулар белән бораулыйлар.* Нефть турында хикәяләр

**ША́Р СУГЫШЛЫ** *и.* Кәшәкә таяк белән кечкенә тупны яки шуңа охшаш берәр йомры әйберне сугып йөртүдән гыйбарәт уен. *Кая карама хатыны-кызы, баласы-чагасы капка төбенә чыгып утырган: балалар уйный, хатын-кызлар гәп тоталар, ә арырак малайшалай шар сугышлы уйный, бериш казык ярышы уены белән мавыккан.* М.Хәбибуллин

**ША́РСЫМАН** *с.* Шар рәвешендәге, формасы белән шарны хәтерләткән. *Туп «шар уенчык» һәм туп «пушка» сүзләренең бердәйлеген аңлар өчен, борынгы снарядларның шарсыман булуын искә төшерергә кирәк.* Р.Әхмәтьянов

**ШАРТ** I *и. гар.* **1.** 1) Билгеле эшгамәлнең үтәлешен, башкарылуын, тормышка ашуын тәэмин итә торган

уңай хәл, мөмкинлек. *Шуның кебек үк, талантларның ачылуы, үсүе, камилләшүе ечен дә шартлар кирәк.* Ә.Мәхмүдов. *Монда, төрле милләтләр берберсе турында яхшырак белсен өчен, шартлар тудырылачакмы?* Н.Алан

2) Тормыш, көнкүреш үтә торган тирәлекнең географик, тарихи, иҗтимагый һ.б.ш. факторларга бәйле үзенчәлекле яклары. *Һәр тарихи күренешнең үсеш дәрәҗәсе, масштабы – зурлыгы объектив һәм субъектив шартларга баглы.* Р.Әхмәтьянов. *Аспирантурада калганнарның яшәү шартлары начар, фатирлар юк дәрәҗәсендә.* М.Галиев

3) Үтәлүе рәсми килешү яки алдан сөйләшү нигезендә мәҗбүри итеп каралган төп таләп. *Апа, сезгә дәваланырга кирәк, дип табам. Әмма бер шартым бар.* И.Юзеев. *Егетләргә, өч тәүлектә әйләнеп кайту шарты белән, махсус самолёт биреп бирелде.* Р.Корбан. *Димәк, мин Мөхәммәдәмингә шундый шартлар куярга тиешмен ки, көчәнә-көчәнә, күзләре шартлап чыксын.* М.Әмирханов

4) Билгеле урында, билгеле вакытта барлыкка килгән вазгыять, хәлләрнең билгеле торышы. *Теләсә нинди шартларда беренче бөртекләр элеваторга озатылырга тиеш.* К.Миңлебаев. *Русиядә хәзер вазгыять шундый ки, Татарстан җитәкчесенең сәяси фигура булуга караганда, күбрәк икътисад белән шөгыльләнүе әһәмиятлерәк булыр кебек. Бу ничә ел дәвам итәчәген әйтүе кыен, әмма хәзерге шартларда Миңнеханов – күпкә кулайрак кеше.* Д.Исхаков

5) *мат.* Берәр нәрсәнең нигезендә яткан билгеле мәгълүмат, төп фикер. *Мәсьәләнең шарты. Теореманың шарты*

6) Торакта булырга тиешле су, газ, канализация кебек көнкүреш уңайлыгы. *Миргалим Харисов шартлары булмаган кечкенә бүлмә алды, Әзһәр белән Таҗи шартлары булмаган икесенә бер бүлмәгә күченде.* Р.Батулла

**2.** *хәб. мәгъ.* Кирәк, мәҗбүри, тиеш. *Безнең гомуми мәнфәгатьләребез өстенлек итәргә тиеш. Ә моның өчен бергә җигелеп эшләү шарт.* А.Тимергалин. *Чәе гап-гади: сөтсез, тәмтомсыз, үлән-төнәтмәсез, бары коры чәй. Әмма куелыгының кәефенә тәңгәл килүе шарт.* М.Әмирханов

**3.** *с. мәгъ. лингв.* Атап үтелгән эш-хәрәкәтнең үтәлеше өчен кирәк булган нәрсәне белдерү белән бәйле. *Шулай ук шарт фигыль формасы, нәтиҗә өлешеннән башка кулланылып, шартлы теләк наклонениесенә хас теләк, үкенү, йомшак өндәү кебек мәгънәләр белдерә ала: Ичмасам, бала-чага ата-анасы булмасагыз икән (Ф. Хөсни).* Татар грамматикасы. *Шарт фигыльне яратып бетермим.* Сөембикә

◊ **Шарты килү** Һәр яктан да туры килү, тиешенчә килеп чыгу, бөтен таләпләргә җавап бирү. *«Газ плитасы – газ плитасы шул инде. Ризыкның шарты бик килми. Менә авыл мичендә пешерсәң иде!» – дип сөйләнгән иде.* В.Нуруллин. **Шартына җиткерү** *к.* **шартын китерү**. *Шик юк, өй эчтән дә шартына җиткереп, нык итеп, пөхтәләп эшләнгән иде.* Ә.Еники. **Шартын туры китерү** *к.* **шартын китерү**. *Без, аның белән янәшә утырып, чи тиредән унике чатлап икебезгә ике камчы үрдек. Борынгыча иттереп, бөтен шартын туры китереп.* М.Маликова. **Шартын китерү** Җентекләү, тәфсилләү, бөтен таләпләргә җавап бирерлек, тиешенчә эшләү. *Син бит аларны зур кунак бүлмәсендә бөтен шартын туры китереп каршы аласың.* А.Нәҗми. *Нияз йотылып китап укый, аз-маз кәгазь тырмаштыргалый, бөтен шартын китереп, хасиятләп вермишель пешерә.* В.Нуриев

**ШАРТ** II *иярт.* 1) Каты коры нәрсә ярылу, чатнау, сыну тавышын яки ату, шартлау вакытында барлыкка килгән тавышны белдерә. *Малай бер таянган иде, ди, шартаяк шарт итеп сынды, ди.* Әкият

2) Берәр эш-хәрәкәтнең кисәк кенә, кинәттән булу, үтәлү рәвешен белдерә. *Каты агач шарт сынар, черегән агач кырык ел чыдар.* Мәкаль

◊ **Шарт сыну** 1) Карарны тиз кабул итү, мәсьәләне тиз хәл итү, озак уйлап тормастан тәвәккәлләү; 2) Кисәк кенә үлеп китү

**ШАРТАЯК** *и.* Кечкенә туп яки алканы сугып уйнар өчен бер башы кәкрәйтеп ясалган таяк; кәшәкә. *Камыр малай төн үсә, көн үсә, ай үсәсен көн үсә, ел үсәсен ай үсә. Бабай ясап бирде, ди, моңа шартаяк.* Әкият. *И көләч йөзле малай, йөргән малай яланаяк! Бер дә тыштан кермичә уйнап йөрүче шартаяк!* Г.Тукай

**ША́РТ ИТҮ** *ф.* Шарт кебек тавыш чыгу. *Шарт итеп мылтык шартлауга, чыйк итеп чалкан әйләнде дә төште.* Г.Мөхәммәтшин. *Шул көннән башлап, куяннар шарт иткән тавыштан да куркып гомер кичерәләр, ди.* Г.Гыйльманов // Шундый тавыш чыгарып шартлау, сыну. *Унберенче сыйныфта дәрес алып бара иде, нәрсәдер шарт итте – кабартылган шарны шартлатканнар икән, кемдер фьют дип сызгырып куйды – дәрес өзелде.* Н.Көбәш // Кисәк сынып китү, шартлау һ.б.ш.

**ШАРТЛАВЫК** *и.* **1.** 1) *бот.* Канәферчәләр семьялыгыннан киң таралган, орлыгы өлгергәч, тартмачыгы шартлап ачыла торган күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* **смолёвка, хлопушка**. *Бу – күзлут нәкъ үзе, дип, Давыл чәчәге, меңьяфрак, Шартлавык, зәңгәр казаяк, Гөләп, чыпчык күзе, дип!* Ш.Галиев. *--- эксперимент кысаларында галимнәр, Себердә табылган тар яфраклы шартлавык (чүп үләне) орлыкларыннан яшәүгә сәләтле фрагментларын аерып алып, аларны туклыклы мохиткә урнаштырганнар.* Өмет

2) Шартлый торган нәрсә; шундый уенчык төре. *Шабан көлә, шар ярып: – Шундый да шәп шартлады. Шар түгел бу – шартлавык! Мин торам тел шартлатып, Шаянлыкка шаккатып.* Г.Әпсәләмов. *Бенгаль утлары 10 – 100 сум, шартлавыклар 10–20 сум, чыршы уенчыкларының һәрберсе 30 сумнан да ким түгел.* Татарстан яшьләре

3) *күч.* Мактанчык, буш сүз сөйләргә, шапырынырга яратучы кеше. *Син, кызыңа кияү эзләп, шул шартлавыкны безнең арага тыктың!* К.Тинчурин

**2.** *с. мәгъ.* 1) Шартлый торган, шартлау ихтималы (куркынычы) булган

2) *лингв. к.* **шартлаулы**. *Һәмзә дип йөртелгән шартлавык тартыкны э хәрефе белән бирдек.* М.Мәхмүтов

3) Буш, бернинди эш-гамәл белән дәлилләнмәгән (сүзләр тур.)

4) Мактанырга яратучан, шапырынучан (кеше тур.)

◊ **Шартлавык шартлату** 1) Бушка мактану, шапырыну. *[Галиәкбәр агай] авылның өч-дүрт бөртек картына сер итеп кенә үзенең дә элекке мулла икәнлеге турында шартлавык шартлатты.* Г.Мөхәммәтшин; 2) Эшләмичә тик йөрү

**ШАРТЛАМА** *с.* Бик көчле, зәһәр; чатнама (салкын тур.). *[Миңнулла:] Күрдеңме, шартлама суыкта тимер катнаштырдым бит.* И.Гази. *Кыш уртасы, Кыл уртасы – Шартлама салкын сына.* Н.Сафина

**ШАРТЛАТКЫЧ** *и.* **1.** 1) Берәр тышкы тәэсир яки эчке процесс нәтиҗәсендә шартлап, җылылык һәм газлар бүлеп чыгара торган химик матдәләр, кушылмалар яки аларның катнашма-

сы; *русчасы:* **взрывчатое вещество**. *Ул риза. Шартлаткыч белән детонатор-взрыватель табу гына кыен булыр, ди.* Г.Әпсәләмов. *Хәзер менә комиссия төзеп, кем гаепле икәнен тикшерәчәкләр: шартлаткыч сыйфатсыз булганмы, әллә шартлату эше дөрес башкарылмаганмы?* М.Маликова

2) Шундый матдә нигезендә ясалган, хәрби максатларда, тау яки җир эшләрендә һ.б.ш.да кулланылган шартлату җайланмасы; *русчасы:* **взрывчатка**. *Моннан ике чакрымнар өстәрәк шурфлар тишеп, шартлаткычлар куйган идек.* А.Хәсәнов. *Ул җан ачуы, әллә нинди кыргый көч белән алга тартылды, бар булмышы белән хәзер, менә хәзер шартлаячак шартлаткычны хәтерләтеп, ашык-пошык сөйли, үз халәтен аңлата башлады.* А.Хәлим

3) Шундый җайланманың хәрби максатларда кулланыла торган төре, сугышчан коралның бер формасы; мина. *Ә авыл җирендәге китапханә акрын хәрәкәт итүче шартлаткыч кебек: ул гасырлар өчен эшли, акрын, эзлекле, әмма нәтиҗәле эшли.* М.Мәһдиев. *Тыңлап карарга кирәк, шартлаткыч булса, тек-тек итеп сәгате эшләргә тиеш аның.* З.Хәким

4) Артиллерия снаряды, мина, авиабомба, ракета кебекләрдәге төп шартлый торган матдәне яндырып җибәрә, җайланманы хәрәкәткә китерә, шартлата торган өлеше; *русчасы:* **взрыватель**. *Шартлаткычларны саклый торган шкафын Таһир юри ачык калдыра башлады.* А.Хәсәнов. *Немецлар аларны [миналарны] тимерьюлны шартлатырга дип китергән булган, тик өлгерә алмый калганнар. Ә шартлаткычларын күптән алдым инде мин аларның.* Р.Мостафин

**2.** *с. мәгъ.* Шартлату өчен кулланылган, шартлата торган. *Штректа шартлаткыч патроннар тутыру өчен шпурлар, шурфлар тишкәндә, киң күкрәкле, Алып батырдай гәүдәле төрек егете Мостафа белән дуслашты Таһир.* А.Хәсәнов. *Г.Вәлиевнең фәнни эшчәнлеге дары, шартлаткыч матдәләр һәм эчке баллистика проблемаларына багышлана.* Г.Мөхәммәтшин

**ШАРТЛАТУ** I *ф.* 1) *төш. юн. к.* **шартлау**. *Атмосфераның югары катламнарында яки космоста скафандр кешене тышкы басымнан сакламый (анда ул нуль чамасында була), ягъни чынлыкта моның нәкъ киресе күзәтелә: скафандрсыз булганда, эчке басым кан юлларын шартлатырга мөмкин.* А.Тимергалин

2) Шарт иткән кискен тавыш чыгару. *Уң аягы белән, Габдрахманның аягы янына ук китереп, чаңгысына басты да, ике куллап тотып аны шартлатып сындырды. З.Зәйнуллин. – Бүтән комачаулама, – диде һәм тешләрен чытырдатып кысты да эһ дигәнче ручканы шартлатып сындырды.* Л.Лерон

3) Шартлаучан матдә яки махсус шартлаткыч җайланманы хәрәкәткә китерү, эшләтеп җибәрү. *Исәбе ярдан шуып төшеп немецлар арасына керергә дә, шунда соңгы гранатаны шартлатырга иде.* З.Зәйнуллин // Шартлаучан матдә яки махсус шартлаткыч җайланма ярдәмендә берәр корылма, урын яки предметны җимерү, таркату, юк итү һ.б.ш. *Күперне шартлатып, бронепоездның юлын кисәргә кирәк.* Г.Кутуй. *Яшь гвардиячеләр немецларның складларын, ягулык базаларын шартлатканнар.* Х.Камалов

4) Мылтык, туп һ.б.ш. утлы коралдан ату. *Урыс агайларның берсе шатлык билгесе итеп әллә ничә тапкыр мылтык шартлатты, башкаларыбыз кулларны кысарга, кочаклашырга тотындык.* Г.Бәширов. *Ауга йөргәнеңне хәтерләмим, әмма берәрсенең бәбәе туса, өй кыегына менеп, мылтык шартлата идең.* А.Гыйләҗев

5) Утлы коралдан атканда, кискен шартлау тавышы чыгару. *Кинәт кенә шартлатып мылтыктан аткан тавышларга сискәнеп уянып киттем.* Ф.Йосыпов. *Ул арада Колаксыз Гариф, аны-моны уйлап тормыйча, мылтыктан шартлатып атып та җибәрде.* И.Диндаров

6) Берәр нәрсә белән кискен хәрәкәт ясап, һавада шартлау тавышы барлыкка китерү. *Яннарында чыбыркы булса да, мин агайларның атка суккан чакларын күрмәдем, алар чыбыркы шартлату белән чикләнәләр иде.* А.Тимергалин. *Ул ике кулын күтәрде һәм бармакларын шартлатып такмаклый башлады ---.* А.Хәлим. *Соңыннан һәммә укытучы: «Бәй, кыңгырау сары төстә буламыни ул?» – дип тел шартлатты.* А.Гыймадиев

7) *күч.* Кискен, кырыс, кыю, тәвәккәл рәвештә эш итү. *– Бу синмени? – дидем, ишекне шартлатып ябып.* А.Гыйләҗев. *Менә мин үзем егермене дә тутырмаган көе шартлатам да өйләнеп куям!* Р.Батулла

8) *күч.* Уйлап чыгару, ялганлау; шыттыру. *Тыңлап торучы малай «әнекәем!» дип кычкырып җибәрде, ак сакаллы карт: «Шартлата Мәхмүт», – дип куйды. – Биррәһи, шартратмыйм! Ипидер менә!* А.Вергазов

◊ **Шартлатып сындыру** Кешенең фикере, күңеле, сәбәпләре һ.б.ш. шартлар белән исәпләшеп тормыйча, артык кырыс рәвештә, үз фикеренә генә таянып эш итү; үзенә буйсындыру. *Миңа килгән агайлар аның хакында сүз әйтүдән тыелсалар да, мин ишеткән идем инде: Хәйрүш бик усалланган, имеш, бер дә рәхим-шәфкать дигән нәрсәне белми, токан җиреннән шартлатып сындыра, имеш.* Ә.Еники. *Алар әнә гайрәтле ирләрнең дә ихтыярын шартлатып сындыра торган булганнар бит.* Р.Юныс

**Шартлата башлау** Шартлатырга тотыну. *Шул якка табан барып килмәкче дә булган иде, Күк Тәңре утлы камчыларын шарт-шорт шартлата башлагач, кире уйлады, күкрәкчәсенә тегелгән дога-бөтиен капшый-капшый, ашыгып өенә кереп китте.* Г.Гыйльманов

**Шартлатып алу** Кисәк кенә, бер мәртәбә яки тиз арада шартлату. --- *атлары да теләр-теләмәс кенә кыймылдыйлар. Мисбах аларга кычкырмый, тик ара-тирә арт саннары өстендә чыбыркысын гына шартлатып ала.* Г.Әпсәләмов. *Таһирның элекке хәрби моряк булуын белгәч, телен үк шартлатып алды.* А.Хәсәнов

**Шартлатып бетерү** Барысын да шартлату. *Дәүләт чиген уяу пограничниклар, герой кызылармеецлар саклый, чөнки саклап тормасалар, чигебезне шпионнар, диверсантлар, провокаторлар үтеп кереп, халык арасында коткы таратып, завод-фабрикаларны шартлатып бетерүләре бар...* В.Юныс. *Керпе кунакка килгән һәм әниләре белән ялгыш бөтен шарларны шартлатып бетергән.* Л.Закирова

**Шартлатып җибәрү** Кисәк шартлату. *Авылның түбән очыннан кыңгырау тавышы ишетелде; ул тиз якынайды, кучер: «Һа-а-ай!..» – дип кычкырып, чыбыркы шартлатып җибәрде ---.* Г.Ибраһимов. *Рәшәткә башындагы чыбыркыны алдым да, бер-ике мәртәбә кул язу өчен генә айканып алганнан соң, аннары чынлап торып, шәп итеп, урман ягына таба каратып шартлатып җибәрдем.* З.Хөснияр

**Шартлатып карау** Сынау өчен шартлату. *Лагерьда бер бомба шартла-*

*тып карагыз – эсэсчылар хәзер килеп җитәчәкләр.* Г.Әпсәләмов. *Нур бүген камчы ясады, Бөтереп куйды очын. Шартлатып караган иде, Чеметеп алды учын.* Г.Гыйльманов

**Шартлатып кую** Бер мәртәбә шартлату. *Фаш ителү куркынычы узып, йөрәк тибеше тынычлангач, малай телен шартлатып куйды.* А.Тимергалин. --- *Яков Әмир кулындагы бер арканны алды. Аны әүвәл озынайта төште, чыбыркысын бер шартлатып куйды.* В.Имамов

**Шартлатып тору** Даими рәвештә яки әледән-әле шартлату; хәзерге моментта шартлату. *Исең китүдән тел шартлатып торасың, югыйсә еларлмын инде дип барган идем.* Б.Рәхимова. *Моннан 30–40 ел элек булган хәлне бәян итәм, әгәр ул бүген булса, тел дә шартлатып тормаслар, заманга гына сылтарлар иде...* Ә.Галиева

**ШАРТЛАТУ** II *и.* Шартлау энергиясен төрле максатларда куллану теориясе һәм гамәли эшләре. *Син бит үзеңне «минёр» диден. Шартлату осталарын, тәҗрибәле минёрларны, үзебезнең портка ук дүрткуллап алачаклар.* А.Хәсәнов

**ШАРТЛАТУЧЫ** *и. махс.* Шартлату эшләре белгече, шулар белән шөгыльләнүче хезмәткәр. *Авиаторлар бер йортта, геологлар икенче, шартлатучылар, механизатор-бульдозеристлар, ялланып эшләүче гади эшчеләр – һәркайсы үз өйләрендә торалар икән.* А.Хәсәнов. *Аңа шушы чорда өлкән лейтенант дәрәҗәсе бирелә, ул шартлатучы-диверсантлар әзерләү мәктәбендә инструктор була.* Г.Мөхәммәтшин

**ШАРТЛАТЫЛУ** *ф. төш. юн. к.* **шартлату**. *Шартлатылган күпер янына яңадан килгән совет сугышчылары аны елга ярында, туфракка ярылаш күмелеп, һушсыз яткан хәлендә табалар.* Г.Әпсәләмов

**ШАРТЛАТЫП** *рәв.* 1) Кискен хәрәкәт белән; кисәк, кинәт. *Көннәрдән бер көнне бик каты җилле давыл килде дә яшь агачны шартлатып сындырды да китте.* Г.Тукай

2) Вакыт уздырып тормастан, авырсынмыйча, тиз генә, җитез итеп (эшләү тур.). *[Наил] балтаны алды да шартлатып утынны ярып та ташлады.* А.Әхмәт. *Андый вакытта Капитан, «закун» дип тел шомартып тормыйча, сораган нәрсәне шартлатып эшләп бирә.* И.Диндаров

3) Берәр нәрсәне әйбәт белгәнгә күрә, уйланып, икеләнеп тормыйча, тотлыкмыйча, чатнатып (җавап бирү, сөйләү һ.б. тур.). *Урыс посёлогында үскән кызга кыюлык тансык нәрсә түгел, шартлатып урысчасын сөйләшә, чибәрлеге күпләрне көнләштерерлек ---.* Д.Каюмова. *Имтиханга әзерләнгән көннәрдә дә берничә тапкыр кабатлап, хәтердә яңарткан идем мин аны. Менә хәзер ярап куйды: шартлатып яттан әйтеп бирдем.* В.Нуруллин

4) Төгәл, ачык итеп, кистереп, ике фикергә урын калдырмыйча, тәгаен. *«Нигә барасың Төркиягә?» дигән сорауга, шартлатып: «Назыйм Хикмәтнең ватанын күрәсем килә», – дип җавап бирдем.* Б.Рәхимова

5) Оялып, хәтер саклап тормыйча, ялагайланмыйча, турыдан-туры. *Әйтәсе сүземне теләсә кем каршында шартлатып әйтәм!* М.Маликова. *Ачуым чыгып, шартлатып әйтеп салдым: – Син мине тавык дип белдең мәллә? Кәҗә тоягы күрсәтсәм, ни диярсең, ә?!* З.Мәхмүди

6) Тәвәккәлләп, ике уйлап тормастан, үзенә ышанып, кыю, катгый рәвештә. *Мәгәр исән булса, шулай күрәләтә мыскыллаганы, эткә тиңләгәне өчен шартлатып, Гаага халыкара судына биреп, бу сәер майорны төрмәгә утыртып куяр иде.* А.Хәсәнов. *Әллә инде хәвеф-хәтәрдән саклангандай, капкаларны эңгер-меңгердә үк шартлатып бикләү гадәткә керде ---.* Т.Әйди

**ШАРТЛА́У** I *ф.* 1) Шарт иткән тавыш чыгару, шарт итү. *Ерак та түгел корыган яфраклар кыштырдады, чыбык-чабыклар шартлады, җирне тетрәтеп, кемдер атлады.* А.Алиш

2) Каты коры тавыш чыгарып ярылу, чатнау, сыну. *Дөрес, урманда ышык, җил юк, ләкин 40–50 градус салкын. Агачлар шартлап сына.* Т.Биктимирова. *Карт өянкенең ябалдашы шартлап ярылып сынып төште.* А.Нәҗми

3) Утлы коралдан атканда, шартлаткыч матдә хәрәкәткә килгәндә көчле тавыш барлыкка килү. *Габделвәли караңгылык йөта башлаган шәүләгә төзәп тәтегә басты. Шартламады мылтык.* М.Юныс. *Берзаман Чүке елгасы янындагы печән кибәне төбендә наган шартлады...* А.Гыйләҗев

4) Бомба, снаряд, шартлаткыч матдә һ.б.ш. нәрсәләрнең җимергеч көче хәрәкәткә килү. *Менә тагын җир селкенде, бик якында гына снаряд шартлап күккә балчык багана күтәрде, аннан тагын.* М.Мәһдиев. *Йөз мең офицер һәм солдат, бронетранспортёрларга төялеп, һөҗүмгә күчтеләр. --- Туплар залпы яңгырады, миналар шартлады, ядрәләр чәчелде.* Т.Миңнуллин

5) Шартлату көченнән җимерелү, челпәрәмә килү, шартлатылу. *Бу бит әле завод шартлаган дигән сүз түгел.* Р.Ишморат. *Беләсеңме, шартлаган атом станциясе өстендә алар [шарсыман яшеннәр] аяз көнне дә күренә.* А.Тимергалин

6) Зур басым яки авырлык, артык югары яки түбән температура һ.б.ш. тәэсирендә ярылу, чатнау, өзелү. *Малик кармак җебен бушатырга өлгерә алмый калды, җеп шартлап өзелде.* М.Хәсәнов. *Тыгызлап ябып су кайнатсаң, чуен казан да шартлый.* М.Маликова

7) *күч.* Ачу, гарьлек, көнчелек һ.б.ш. хисләрне үтә көчле кичерү, соң дәрәҗәсенә җитү, нишләргә, үзен кая куярга белмәү. *– Белмим, – дидем мин, ачуымнан шартлардай булып.* А.Гыйләҗев. *Без ешрак салып һәм каядыр кунып кайтсак, хатыннар да шартлый.* Ф.Баттал

8) *күч.* Үтә көчле тойгы-кичерешләрне тыя алмау, ирексездән тышка бәреп чыгарга бирү. *Бюрода шулай итеп җырлап җибәрсәң, нишләрләр иде икән, әй! Валлаһи, шартларлар иде!* Г.Галиева

9) *күч. иск.* Бөлү, банкротлыкка чыгу, банкрот булу. *Күп тиҗарәт фирмаларының шартлауларының сәбәпләре дә шуннандыр.* Г.Камал. *Ул чордагы татар сәүдә буржуазиясе арасында Москва фабрикантларыннан көтәргә күпләп мал алып, соңыннан шартлаган булып банкротлык игълан кылу бик модадагы әйбер иде.* М.Гали

10) *күч.* Бик күп итеп, туйганчы, гарык булганчы ашау, эчү. *Бар бит кешеләр дөньяда! Шартлаганчы ашаттылар да тагын капчыкка да төяп җибәрделәр.* И.Гази

11) *күч.* Тормышка ашмау, акланмау, буш булып чыгу. *Мин дә сиздем шунда, мескен гыйшкым кызган куык төсле шартлады.* М.Җәлил

◊ **Шартлар дәрәҗәгә җитү** Ачу, ярсу һ.б.ш.дан нык киерелү, үз-үзен тоту бик авыр булу. *Чырае шартлар дәрәҗәгә җитеп бүртенде, чөгендер кебек кызарды.* А.Тимергалин. **Шартласа да** Бик теләсә дә, бар көченә тырышса да барып чыкмау турында. *Җылау түгел, шартласа да, Сәләхи минеке!* А.Гыйләҗев

**Шартлап бетү** Барысы да шартлау. *Куйсалар да шартлап беткәннәрдер,*

*чөнки артиллеристлар бу төшләрне дә бик еш снаряд белән тапаганнар, бар җир актарылып ташланган, чокырлардан ачы төтен күтәрелеп ята иде.* Х.Камалов

**Шартлап китү** Кинәт шартлау. *Урынга ятасың – урак урган чактагыдай бил сызлый, вакыты белән аяк буыннары бикләнәләр, шартлап китәләр.* А.Алиш. --- *шул куык белән шаярып утыра башлады. Боргычлый торгач, ялгыш шартлап китте бит моның куыгы.* В.Нуруллин

**Шартлап тору** Даими рәвештә яки әледән-әле шартлау; хәзерге моментта шартлау

**Шартлый башлау** Шартлый язу; шартларга тотыну. *Машинаны да ял иттерәләр. Гранаталар детонациядән дә шартлый башлый.* А.Гыйләҗев. *Ютәлләү тавышы – һәм бераздан, выжылдап килеп, окоп кырыенда гына миналар шартлый башлый.* Х.Камалов

**Шартлый тору** Бер-бер артлы шартлау, әледән-әле шартлау. *Куыкның озак тормый шартлавы ачык билгеле нәрсә инде ул. Менә безнең куыклар да берәм-берәм шартлый тордылар...* А.Тимергалин

**Шартлый язу** Чак шартламый калу. *Минем курска барасын ишеткәч, шартлый язды малаең!* А.Гыйләҗев

**ШАРТЛА́У** II *и.* 1) Шартлау I (*4 мәгъ.*) күренеше. *Ике кул пулемётының ут сиптерүенә гранаталар шартлавы, мылтыклардан атулар кушылды.* З.Зәйнуллин

2) Шартлау I (*4 мәгъ.*) тавышы. *Бөтенебез әниемнең мәете өстендә үкерешеп утырганда, якында гына коточкыч шартлау яңгырады.* Г.Рәхим. *Шартлау бөтен тирә-юньне яңгыратачак һәм КГБ лейтенантының баскан урынын упкын итәчәк!* М.Маликова

3) *күч.* Кешегә көчле тәэсир иткән тетрәнү, стресс, психологик травма кебек хәлләр. *Кешенең язмышында кискен көчәнеш, шартлау, авыр югалту булмаса, гакылы озакка җитә икән.* Т.Галиуллин

4) *күч.* Иҗтимагый тормышта кискен үзгәреш, гадәти тормыш агымын үзгәрткән тетрәндергеч вакыйга. *Соңыннан бер көндә сизмәстән күпчелек алдынгылар ягына ауды да куйды һәм җыелышта шартлау булды.* Т.Гыйззәт

**ШАРТЛАУЛЫ** *с. лингв.* Тоташкан сөйләм органнары кисәк ачылып, шуннан узган һава агымы шартлауга охшаш шау чыгару нәтиҗәсендә барлыкка килгән, эксплозив. *Шартлаулы тартыклар*

**ШАРТЛАУЧАН** *с.* 1) Шартлау үзлеге булган, шартлый торган. *«Селитра»ның икенче тәрҗемәсе – барут тозы (дары тозы) – $NaNO_3$ кушылмасының янучан, шартлаучан матдәләр составында, мәсәлән, дарыда файдалануын аңлата.* Фән һәм тел. *Иректе рәвештә корал, шартлаучан матдәләр тапшыручылар җинаять һәм административ җаваплылыктан азат ителәләр.* Сарман

2) *күч.* Четерекле, проблемалы, бик тиз бозылу, җимерелү ихтималы булган. *Коллегалар, без сөйләшә торган тема шартлаучан, әйдәгез, керосин сипмик!* Татарстан яшьләре

**ШАРТЛЫ** *с.* **1.** 1) Билгеле кешеләр арасында алдан килешенгән, шул кешеләргә генә билгеле булган, шулар гына аңларлык. *Ашыгыч һәм яшертен йомышлар калыкса, алар шартлы сүзләр белән телефоннан хәбәрләшәләр дә (телефон шуннан бүтәнгә ярамый!) очрашалар ---.* А.Гыйләҗев. *Без инде, берәр лазутчик иптәшенә шартлы сигнал бирә торгандыр, дип уйлыйбыз.* Р.Батулла

2) Билгеле шарт белән чикләнгән, билгеләнгән; берәр шарт үтәлгәндә генә гамәлдә булган, шуның үтәлешенә бәйле, берәр шарт үтәлүен таләп итә торган. *Миңа бер ел шартлы сынау вакыты бирелде.* Э.Фатыйхова. *Шунлыктан игүле кузаклы үләннәрнең күбесе шартлы агулы үсемлекләргә керә.* Агулы үсемлекләр. *Шартлы килешү*

3) Җәмгыятьтә, билгеле даирәдә яки кемнәр арасындадыр кабул ителгән кагыйдә, норма, караш, гадәтләргә туры килә торган. --- *бәхет үзе – үтә шартлы һәм чагыштырма төшенчә. Бәхет ул бүген бар, иртәгә юк. Берәүгә – бер нәрсә бәхет, икенчегә – икенчесе бәхет.* Г.Хөсәенов. *Мәхәббәт һәр очракта да шартлы киртәләрне, чикләрне язгы ташкын кебек җимереп үтә торган хисси шашкын, тиле көч булырга тиешме, син андый мәхәббәтнең яшәвенә ышанасыңмы, Сәет?* Т.Галиуллин

4) Чынбарлыкта булмаган, күзаллаган, фаразланган, уйланылган. *Азия белән Европа арасындагы шартлы чик Кавказ буйлап үтә.* А.Тимергалин. *Алтын Урда чорында этник процессларга Идел-Урал регионы һәм Дәште Кыпчак арасындагы элек тә күбесенчә шартлы чикләрнең юкка чыгуы нык тәэсир итә.* Б.Хәмидуллин. *Социаль статуслар ул вакытта шартлы, ай-һай, бик тә буш сүзләр иде әле.* Л.Әбүдәрова // Берәр уку йорты, хәрби өйрәнүләр һ.б.ш. ның кагыйдәләрендә, таләпләрендә каралган; билгеле шартлардан, кагыйдәләрдән чыгып, мисал өчен алынган. *Булдырдыгыз, егетләр! Һавада вакытта ук ут ачып, сез «дошман»ның алгы позициясендә торган шартлы көчләрен чигенергә мәҗбүр иттегез.* Р.Вәлиев. – *Дошман белән очрашканда нишләрсең? – Ул бит шартлы дошман.* Р.Могыйнов

5) Берәр реаль предмет, күренеш, корылма һ.б.ш.ны белдергән символик сурәте, билгесе, тамгасы булып торган; шундый билгеләр ярдәмендә аңлата торган. *Самолёт биеклек алды, барысы да топография картасындагы шартлы билге сыман шакмакларга әйләнде.* М.Мәһдиев. *Картага үлән төре шартлы билгеләр белән төшерелә яисә сүз белән языла.* Агулы үсемлекләр

6) Сәнгатьнең берәр төрендә, юнәлешендә генә кабул ителгән чаралар, алымнар белән гәүдәләндерелгән. *Аның иҗаты артык куе һәм шул ук вакытта шартлы романтик сурәтләрдән котылып, психологик реализм һәм нечкә лиризм юлы белән үсә.* Р.Мостафин. *Ул бу спектакль өчен заманча декорация – җиңел һәм шартлы пейзаж иҗат итәргә, берничә калку деталь ярдәмендә бүлмә, торак төшенчәсен бирергә булды.* Т.Әйди

7) *махс.* Берәр эшнең күләмен билгеләгәндә, ресурсларны һ.б.ш.ны исәпләгәндә башлангыч, таяну берәмлеге итеп алынган. *Район тарихында тәүге тапкыр бер баш шартлы терлеккә 55 центнер азык берәмлеге тупланды.* Т.Нәҗмиев. *1993 елның игеннәрен урып җыю сезонында гына да 2153 шартлы гектарда эш башкарды, тракторчыларның район ярышында янә беренче урынга чыкты һәм хакимият тарафыннан «Урал» маркалы мотоцикл белән бүләкләнде.* Г.Мөхәммәтшин

8) *физиол.* Тумыштан булмаган, организмның яшәве барышында барлыкка килгән, баш миенең эшчәнлеге белән бәйле (рефлекс). *Тик Фира аны тыңламый, --- нindидер сигнал белән шартлы рефлекска өйрәтелгән җәнлек шикелле, алга талпынды, ишек төбе баскычындагы төенчеген эләктерде дә капкага атылды.* Х.Камалов. *Балыкта*

*шартлы рефлекс тудыру өчен җайсызрак җир бу...* А.Тимергалин

9) Билгеле уңайлыклары булган, шартлар белән тәэмин ителгән. *Кеше матур киенергә, дөрес һәм тәмле тукланырга, яшәр өчен яхшырак шартлы өйләр төзергә өйрәнгән.* А.Нәҗми

10) Ясалма, уйдырма; нәрсәнедер чикли торган, катып калган. *Ниндидер шартлы калыплардан читләшү генә чын яңару була алмый.* М.Гайнетдин. *Зәки Вәлиди һәм Ильяс Алкин җитди сөйләшүгә әзер. Мирсәет тә, ниһаять, шартлы рәсмилектән арына төшеп сөйләргә керешә ---.* Р.Мөхәммәдиев

11) Уртача сыйфатлы, әллә ни әйбәт булмаган; түбән сыйфатлы. *Татар халкының бүгенге шартлы мөстәкыйльлеге, башка төрки халыкларының ирекккә, азатлыкка омтылышлары ни дәрәҗәдә?* Ә.Нәҗипова-Зиннәтуллина

12) *лингв.* Атап үтелгән эш-хәрәкәтнең үтәлеше өчен кирәк булган шартны белдерү белән бәйле. *Татар телендә шартлы теләк наклонениесенең булыр иде формасын 1801 елда басылган хезмәтендә беренче булып И. Гиганов күрсәтә. Шартлы теләк наклонениесендә ул дүрт форма керткән: -р иде (төп форма), -ган булыр иде, -ачак иде, -а иде.* Татар грамматикасы

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Билгеле шарт белән, аерым шартның үтәлүенә карап. *Соңыннан белдем: бу тулай торакта шартлы рәвештә төрмәдән азат ителгәннәр яши икән.* Р.Кәрами

2) Чагыштырмача рәвештә; гадәтидән кайбер чыгармалар ясап. *Хәер, бу вакытны иртә дип атау шартлы рәвештә генә әйтү иде, чөнки тышта әле дөм караңгы, сәгать унберләрдә генә яктырачак.* И.Хуҗин. *Иске елга буендагы төрле-төрле чәчәкләр, үләннәр белән капланган тигез урынны авыл кырые дип шартлы рәвештә генә әйтергә мөмкин иде.* Я.Шәфыйков

3) Фараз итеп, күзаллап; акылда гына

4) Чама белән, якынча, билгеле дәрәҗәдә; нисбәтән, чагыштырмача. *Хәзерге әдәби процессны шартлы рәвештә зур симфоник оркестр белән чагыштырып булыр иде.* М.Хәсәнов

5) Ясалма рәвештә

6) Схематик рәвештә, чынбарлыкка төп-төгәл туры китермичә; символик, образлы итеп. *Шул ук Миңнуллинның икенче әсәре – «Миләүшәнең туган көне» исә бөтенләй заманча шартлы итеп сурәтләнгән.* Т.Әйди. *Бүгенге көндә шартлы рәвештә Нугай далалары дип аталган җирләрдә 50 меңгә якын нугай яши, калган 40–50 меңе дөньяның башка илләрендә көн күрәләр.* Ф.Бәйрәмова

**ШАРТЛЫЛЫК** *и.* 1) Билгеле шарты булу, аерым шартлар, таләпләр куелган булу. Азат ителүнең шартлылыгы

2) Өлешчә генә дөреслеккә туры килү, чагыштырмача дөреслек. *«Сүз ирege» дигән сүздә күпмедер шартлылык бар. Нинди генә заман, нинди генә катылыклар булмасын, Сүзне тыю мөмкин түгел.* Р.Фәйзуллин // Якынчалык, фаразлылык. *Тәнкыйтьченең әлеге күзәтүләре билгеле бер системага салынып, дәреслек-кулланмада чагылыш тапты. Мондый бүленештә билгеле бер шартлылык бар.* Ә.Закирҗанов. *Зиратларны «иске» яки «яңа» дип әйтүдә дә шартлылык бар. Мәсәлән, шул ук Тәбәрле авылының хәзерге зиратына беренче мәртәбә XIX гасыр башында, ягъни ике йөз ел чамасы элек җирли башлаганнар.* Гасырлар авазы

3) Җәмгыятьтә, берәр даирәдә гомуми кабул ителгән һәм гадәт буенча, кирәк булса да, булмаса да, традициягә ияреп кенә үтәлә торган кагыйдәләр. *Туган көннән алып үлемгә Еллар санау – Бары бер шартлылык.* М.Шабаев. *Күрәсең, без, кешеләр һәм милләтләр, чәчәкләр һәм үсемлекләр үстергәндәге шикелле, чынбарлык шартлылыкларын инкяр итәбез һәм отылабыз.* А.Хәлим

4) Билгеле кысаларда катып калу күренеше; чиклелек, чикләнгәнлек. *Монда кешелекнең үз-үзенә тудырган психологик төрмәләрдән, мәгънәсез шартлылыклардан китеп, чынрак яшәеш өчен уянуы турында сүз бара.* И.Вәлиулла. *Һәрвакыт алга бара, ниндидер шартлылыкларны, кемнәргәдер буйсынуны, искелеккә ябышып ятуны җене сөйми.* Ватаным Татарстан

5) *әд.* Сәнгатьнең берәр төрендә, юнәлешендә генә кабул ителгән чаралар, алымнар җыелмасы; символиклык, образлылык. *Аның драма һәм комедияләрендә арттыру да, беркадәр шартлылык галәмәтләре дә бар.* А.Әхмәдуллин. *Ул әле карап узган театрлы тамашалардан үзенең тотрыклы сюжетка ия булуы белән аерыла. Уенда киенепбизәнеп образга керү юк, шартлылык көчле.* Р.Ягъфәров

**ШАРТНАМӘ** *и.* 1) Кул куючы тарафларның үзара бурычлары күрсәтелгән, ике ятан да имзаланып расланган язмача килешү. *Җир вәкилләре белән ике якка да файдалы булган шартнамә төзергә ниятли [Алтынбаш].* Р.Сәгъди

2) *тар.* Урта гасырларда төрки, шул исәптән татар дәүләтләре белән рус кенәзләре алышкан килешү грамоталарының атамасы; *русчасы:* **договорная грамота, шертная грамота, шерть**. --- *Мәскәүдән Василий илчеләре Иван Пулев белән Сура Нихай Казанга килеп, урыс тоткыннарын азат итәргә, орышта ганимәт төшкән барлык коралларны Мәскәүгә кайтарырга вә һәр елны зур күләмле ясак түләп торырга диелгән шартнамәне Сафа Гәрәй ханга тапшырды.* Р.Батулла. *Патша архивында Казан ханнарының шартнамә грамоталары, Казан феодалларының шартнамәләре исемлекләре һәм татарча язулары, башка документлар сакланган була.* Б.Хәмидуллин

**ШАРТСЫЗ** *с.* **1.** 1) Шарт куелмаган, билгеле шартлар белән чикләнмәгән, абсолют. *Кечкенә бала әни назына туймаса, шартсыз мәхәббәтне – мин сине нәрсә өчен дә булса түгел, ә бары булганың өчен яратам дигәнне сизеп үсмәсә, баланың еш авыруына гаҗәпләнәсе түгел.* Шәһри Казан

2) Билгеле шартларга бәйле булмаган; билгеле шартларга бәйле барлыкка килмәгән; тумыштан булган, үзлегеннән барлыкка килгән, табигый. *Шартсыз рефлекслар нәселдән бирелә, шуңа күрә аларны тумыштан килгән рефлекслар дип тә атыйлар.* Биология

3) Яшәү, эшләү һ.б.ш. өчен тиешле шартлары, уңайлыклары булмаган. *Дамир бер ел яшәде шул шартсыз, кыек бүлмәдә, ике ел яшәде, аннан соң янәдән театрга күченеп килде.* Р.Батулла. *Шартсыз чакта – мин 18 ел ятакханәдә тордым – анда минем язу өстәлем юк иде.* Сөембикә

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Чыгармасыз, абсолют рәвештә, мотлак. --- *менә тормышны да шулай бер шартсыз кабул итсәң иде, аның әллә кай якларын уйламасаң иде. Ничек бар, шул көенчә алсаң, тормыш әнә нинди матур, нинди тирән.* Г.Әпсәләмов. *Гадәттән тыш вакыйгалар бәйрәмнәрне бозмасын өчен, янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен шартсыз үтәргә кирәк.* Алга

2) Бернинди шарт куймыйча, бәхәссез. *Түләү мәсьәләсендә дә бакча хуҗасы отты. Юныска артык акча кирәк түгел, бары кышлау урын белән аз-маз тамак ялгарлыкка бернинди шартсыз риза булды ул.* А.Гайнуллина

**ША́РТ-ШАРТ** *иярт. к.* **шарт-шорт**. *Захар шарт-шарт басып, идән буенда йөри-йөри дә күрше бүлмәгә кереп китә.* Г.Исхакый. *Ахута дигәч тә, шарт-шарт мылтык атып, кош-корт биздереп йөргән юк.* А.Хәсәнов

**ША́РТ-ШОРТ** *иярт.* Каты коры нәрсәләрнең вакыт-вакыт, өзек-өзек, яңгыравык тавыш чыгарып ярылу, чатнау, сыну тавышын һәм рәвешен яки тәртипсез ату, шартлау тавышларын белдерә. *Төнге балчык суыгында каткан буыннарын коры юкагач сынган шикелле шарт-шорт китереп, Муса үз бармаклары белән казып кергән куышыннан көчкә чыкты да иртәнге сүрән кояшка йөзен куеп ятты.* Ш.Маннур. *Хантимер, тезенә бәреп, шарт-шорт ботак сындырды.* Н.Гыйматдинова

**ША́РТ-ШОРТ ИТҮ** *ф.* Шартлау (*1–2 мәгъ.*). *Шарт-шорт итеп коры ботаклар сынды.* А.Хәсәнов. *Ат барабара да, шарт-шорт итеп, тәртәгә тибә иде.* А.Гыйләҗев

**ША́РТ-ШОРТ КИЛҮ** *ф. к.* **шарт-шорт итү**

**ША́РТ-ШЫРТ** *иярт. к.* **шарт-шорт**. *Аннары кискеч белән шарт-шырт итеп аның тәнен урап алган чәнечкеле тимерчыбыкны кисә башладым.* А.Хәсәнов

**ШАРФ** *и. пол.* 1) Муенны, бугазны салкыннан саклау өчен урала торган озынча тукыма кисәге. *Кыш икән, өстендә ак кайры тун, башында козырёклы бүрек булыр. Муенына ак калын шарф уралган. Тун якасы һәрвакыт күтәрелгән.* Г.Гомәр. *Кызыл куртка кигән бер кыз Кызыл шарф бәйләгән. – Кызыл машинасы белән Бүген шәһәр әйләнә. Ул сөйгәнен эзли микән, Әллә болай гынамы? Машинасына утырып, Кич шәһәргә чыгамы?..* Л.Шәех

2) 1917 елга кадәр Россиядә генерал яки офицер званиесенең билгесе булган бәйләвеч яки билбау

3) Берәр спорт клубының, иҗтимагый оешма, һөнәри берлек һ.б.ш.ның үзенчәлекле төсе, символикасы булган, шуларга карауны белдергән аксессуар. --- *меңнәрчә үтә милләтче һәм футбол клубы шарфын таккан яшьләр милләтчел шигарьләр кычкырып, славян йөзле булмаган кешеләргә һөҗүмнәр оештырды.* Л.Харрасова

4) *к.* **шарфик**. *Менә ул, рәшәткә аша сузылып, кулындагы алсу шарфын болгады.* М.Маликова

**ША́РФИК** *и. рус* Хатын-кызлар матурлык өчен бәйли торган җиңел юка шарф. *Чәчләр тузгыдылар; шарфик астыннан котылып, Хөршитнең алсу яңаклары, күзләре, озын керфекләре өстенә чәчелделәр ---.* Ф.Әмирхан. *Кызгылт чия, кызгылт сары бәрәңге басуы өстеннән затлы хатын-кыз муеныннан язгы җилгә таралган ефәк өрфия шарфик кебек сыек төтен үрмәли, бәрәңге сабакларыннан аерыласы килмәгәндәй, буразналар өстенә ятып шуыша.* М.Мәһдиев

**ША́РФЮРЕР** *и. нем.* Германиядә 1925–1945 елларда башлыча СС берләшмәләрендә кече командирларның бер званиесе. *Шарфюрерлар арасында мыскыл итүчеләр дә табыла, дөресрәге, бу аларның вазифасына керә ---.* Г.Әпсәләмов. *Күпмедер вакыттан Отто, шарфюрерлар белән сөйләшеп, мине үз янына посёлоктагы баракка алды.* Х.Камалов

**ШАРЫ́К-ШАРЫК** *иярт. к.* **шарык-шорык**. *Шундый да тәмле һәм озак итеп көпә-көндез дә йоклап була икән, дип, шарык-шарык көлешә студент кавеме.* Ә.Баян. *Серёжа шарык-шарык көлергә тотынды.* Ф.Яруллин

**ШАРЫ́К-ШОРЫК** *иярт.* **1.** Берничә яки күп кешенең тавышланып, шаулап, шаркылдап көлүеннән чыккан тавышны белдерә

**2.** *рәв. мәгъ.* Шундый тавышлар чыгарып, шаркылдап. *Аның тозсыз мәзәгеннән сыйныф шарык-шорык көлде, ә мин әллә нишләдем!* Н.Гыйматдинова. *Бер мизгелдә ул шарык-шорык анекдот сөйләүче авыл малаеннан мәһабәт прапорщикка әйләнә.* Р.Вәлиев

**ШАРЫ́К-ШЫРЫК** *иярт. к.* **шарык-шорык**. *Янибыздан, шарык-шырык көлә-көлә, бик чибәр ике кыз узып китте.* А.Хәсәнов. *Мин, егылып төшмәс өчен, урындыгыма тотындым, ә балалар шарык-шырык көлә башлады.* Э.Фатыйхова

**ШАРЫЛДАВЫК** *и.* 1) *к.* **шакылдавык** (*1–2 мәгъ.*). *[Карга куганда] агач шарылдавыкны болгап әйләндерә-әйләндерә куллар тала.* М.Әмир

2) Агымның болганып, тавышланып, гөжләп ага торган урыны. *Бу канау төп елгадан бераз тирәнрәк булганга, су шарылдап ага иде. Шуңа күрә елганың бу җирләрен «шарылдавык» дип атадылар.* М.Гыймадиев

3) *куч.* Артык күп сөйләшүче, такылдык; беркатлы, ачыктан-ачык сөйләп бирү гадәте булган кеше

**ШАРЫЛДАТУ** *ф. йөкл. юн. к.* **шарылдау**. *Юынгыч янына үтеп, крандагы суны шарылдатмый гына ача төште, авызын ашык-пошык чайкап, бит алмаларына җиңелчә генә су тидереп алды да, сөртенеп, өстәл янына килде.* А.Хәлим

**ШАРЫЛДА́У** *ф.* 1) Берәр нәрсә көчле агым белән акканда көчле тавыш чыгару; шаулау, гөжләү, шарлау. *Карт өянкеләр белән уратып алынган аулак төбәккә озын гына агач улак куелган, су шул улактан шарылдап агып төшә икән.* А.Вергазов

2) Көчле агым булып, ургылып агу, шарлап агу. *Үткән җомгада мич каргарга керәм дигән идең и-и-ич?.. Яңгыр яуган саен шарылдап агып утыра би-и-ит...* Г.Гыйльманов. *Хафизә шундый көчле итеп сукты ки, Исмәгыйль абзый чирле күзе урынындамы, аннан шарылдап кан китә күрмәсен, исән күзе исән микән дигән курку белән ике кулы белән ике як битен сыпырып төште.* Мәйдан

3) *к.* **шыгырдау**. *Ишек шарылдап ачылды да, аннан такта күтәргән адәм заты килеп чыкмасынмы?!* Җ.Юнысов

4) *куч.* Артык кычкырып көлү, елау һ.б.ш.; артык күп сөйләшү. *Аптырап карап торды-торды да малай кире чыгып йөгерде, әмма бераздан шарылдап елап кире керде.* Ә.Әминов

**ШАССИ** *и. фр.* 1) Автомобиль, трактор һ.б.ш.ның, кузов һәм двигательдән кала, йөртү һәм идарә итү агрегатларының җыелмасы. --- *бик тә кирәкле ГАИ мәгълүматы алынды: мотор һәм шасси номерлары буенча картотекаларыннан янган машинаның кемнеке икәнен ачыклаганнар ---.* Ә.Сафиуллин

2) Самолётның күтәрелеп китү һәм килеп утыру өчен чыгарыла-кертелә торган, махсус рам һәм көпчәклардән гыйбарәт булган өлеше. – *Фаралары шәп моның! Шассилары да нык болай... Фюзеляжы да ярыйсы күренә...* Ш.Бикчурин

3) *информ.* Эченә система платасы (ана плата) урнаштырылган, шуңа калган җайланмалар һ.б.ш. монтажлана торган корпус

**ШАТ** *с. фар.* **1.** 1) Сөенгән, куанган, шатлык кичергән халәттәге, канәгать, күтәренке күңелле, мәмнүн (кеше тур.). *Көләч йөзле, кара күзләре ялтырап торган, бәхетле һәм чиксез шат Газинур, ике кулын алга сузып, үзенең гөләп чәчәгең чакырды.* Г.Әпсәләмов.

*Шәһәрдән авылга килеп төшкән дусты Фазыл --- элгәреге шат, ачык гайрәтле Салихның «борынгы йомыкый суфиларны хәтерләткән укытучыга, тук мещанга» әйләнүен, «рухани үлемен» кискен тәнкыйтьли.* Р.Ганиева

2) Шатлык, сөенеч чагылдыра, белдерә торган. *Мәрьям ачуланмакчы булды, ләкин, бүтәннәрнең шат кыяфәтен күрепме, бүтән сәбәптәнме, ачуланудан тыелып калды һәм саран гына булса да елмайгандай итеп куйды.* Н.Фәттах. *Ул велосипедыннан төште дә, күңел түреннән чыккан шат тавыш белән ягымлы итеп: – Бәхетем миннән алда керсен әле, – диде.* М.Маликова

3) Шатлыклы, күңелле, шатлык, канәгатьлек бирә торган; шатлык белән башкарыла торган. *Күктә самолётлар очты, колакларны тондырып, шат музыка яңгырап торды.* Н.Фәттах. *Шат җырлары белән уйнап-көлеп Китеп бара безнең балачак.* Аманулла

4) Шатлыклы, күңелле; сөенечләр, куанычлар булган, шатлык кичерелгән (вакыт тур.). *Ул шат чакта мин үзем дә чиксез бәхетле идем. Ул шат чакта мин канатлы идем.* М.Кәбиров. *Еш кына шат малай чагын исенә төшерә.* Р.Миңнуллин

**2.** *рәв. мәгъ.* Сөенеп, куанып, шатлык белән. *Шат елмаеп каршы алырсың син, Зәңгәр шәлең салып җилкәңә.* М.Җәлил. *Гел шат яшәү бар кешегә дә насыйп түгел, әмма шатлык кичергән сәгатьләрең, көннәрең булмый калмас, чөнки «Илле җыр» дигән китабың үзе синең илле шатлыгың бит ул!* Н.Нәҗми

**3.** *хәб. мәгъ.* Канәгать, шатлык халәтендә. *– Мин бик шат, – диде шәһәр малае, туфли очы белән җирне чокып.* А.Тимергалин. *Алсу бәхетле, шат иде: ни әйтсәң дә, йөк машинасының кабинасында әле беренче баруы бит.* М.Мәһдиев

**ШАТАЛАК** I *с. сөйл.* **1.** 1) Кыбырсык, тиктормас, тынгысыз. *Хас та йөгерек-шаталак малай. Без, апалары, аңа бар ни, юк ни: ялантәпи уртага төшкән дә, күбәләк кугандай, уңга-сулга тайпылгалап, җилдерә генә.* Р.Камал

2) Җитди булмаган, өстән уйлаучан, җиңел акыллы, җилбәзәк. *Чибәр, сүзчән, көләч, шаян, хәтта берникадәр шаталак булса да, башкага күңелен йөгертмәгән.* С.Поварисов. *Үзең болай шаталак булсаң да, иманлы, әдәпле китап язгансың.* Н.Гамбәр

3) Мактанырга яратучан, бик сүзчән

4) Җитди булмаган, тирәнтен уйлап эшләнмәгән, җиңел карашлы. *– Синең шаталак такмакларың өчен җизнине районга алып киттеләр, – дидем мин, үксеп елый башлап.* В.Юныс

**2.** *и. мәгъ.* 1) Кыбырсык, тиктормас, тынгысыз кеше. *Кылана торгач, бу шаталак башка бер кешенең ашын түктерде.* Р.Батулла

2) Мактанырга яратучан кеше, мактанчык, артык сүзчән кеше; җиңел холыклы кеше, җилбәзәк. *Гомер агышында Газизнең яратып йөргән, һич югында аңа бик ошаган кызлар, хатыннар булмады түгел, булды. Тик ул һәрбер тәүге очрашуда ук килеп ябышырга әзер җилбәзәк, җиңел акыллы шаталаклардан ерак йөрде.* Ә.Салах

**ШАТАЛАК** II *и. диал.* Тубык сөяге. *--- туган якта бу сөякне шаталак сөяге диләр, ә тубык дип тез башына әйтәләр.* Н.Фәттах

**ША́ТИЯ** *и. рус сөйл.* Абруйсыз, эшлексез, килде-китте кешеләр төркеме. *Я, я! Сез монда җыен шатия җыелып, сөйләшеп утырмагыз.* А.Таһиров

**ШАТЛАНДЫРУ** *ф.* Сөендерү, куандыру, шатлык бирү, канәгатьлек хисе уяту. *Бар, балам, йөгер, әниеңне шатландыр!* А.Гадел. *Хөрмәтле иптәшебезнең яше күпмегә җитүгә карамастан, һаман да элеккечә кайнар йөрәкле булып, бетмәс-төкәнмәс иҗат дәрте белән яшәве безне чиксез шатландыра.* Г.Бәширов

**Шатландыра бару** Торган саен ныграк шатландыру

**Шатландыра тору** Әледән-әле шатландыру. *Р.Харис һаман да татар поэзиясенең алгы сафында атлый, укучысын лирикасының яңа юнәлешләре, берсеннән-берсе камил поэмалары белән шатландыра тора.* Фән һәм тел. *Рөстәм Асаев табигать бүләге – тавышын камилләштерү өстендә армыйталмый эшли һәм шуның нәтиҗәләре белән җыр сөючеләрне дә шатландыра тора.* Кызыл таң

**Шатландыра төшү** Бераз шатландыру; тагы да ныграк шатландыру

**Шатландырып алу** Бераз гына, берара шатландыру. *Ходай, иртүк сезгә зур мәшәкатьләр тудырдым, бераз шатландырып алыйм дидеме, көтмәгәндә-уйламаганда сөенечле вакыйга булды.* Ф.Яруллин

**Шатландырып җибәрү** Бераз, җиңелчә яки көтмәгәндә шатландыру. *Бу хәл тәҗрибәсе җитенкерәмәгән Исмаилҗанны шатландырып ук җибәрде.* Г.Әпсәләмов. *--- ерткыч тавышлары гына ишетә иде. Ә кеше тавышы бик шәфкатьле, бик үз, ничектер күңелне шатландырып җибәрә торган.* Х.Камалов

**Шатландырып килү** Күптәннән, элек-электән, эзлекле рәвештә шатландыру. *Әхлак-әдәп, гадәт кануннарын бәян итә, кешене тормышка әзерли, гомере буе күңелен-зиһенен шатландырып, ныгытып, баетып килә.* Ф.Яхин. *Аның [Гакыйл Сәгыйров] рәсемнәре һәм шигырьләре күп еллар кешеләрне дулкынландырып һәм шатландырып киләләр.* Аргамак

**Шатландырып кую** Көтмәгәндә шатландыру. *Ә язучылар кемнәр? Аратирә Галиәсгар биргәли. Фатих сирәк кенә шатландырып куя.* И.Нуруллин

**Шатландырып тору** Гел, һәрвакыт шатландыру. *Ул «Азат хатын»ны кыска-кыска хикәяләре белән бик еш шатландырып тора иде.* К.Тимбикова. *Табигать тә гел шатландырып кына тормый.* Н.Каштанов

**ШАТЛАНУ** *ф.* 1) Шатлык хисе кичерү, шат булу, куану, сөенү. *– Юк, – мин әйтәм, – ул эчү түгел, тәмәкене дә авызына якын китерми, – дигәч, карчык шатлана.* А.Алиш. *Болар инде – авыруларны терелтү сөенечен --- кичергән, дөрес дәвалау юлын табып шатланган, ялгыш диагноз өчен төннәр буе газапланган кешеләр.* Г.Әпсәләмов

2) Канәгатьлек хисе тою, кинәнү. *Хәлим, үзенең файдалы эш эшләгәненә шатланып, әрле-бирле йөрде.* Г.Гобәй. *Төлкебикә, күзләрен ачып, як-ягына карана. Үзләре генә калганга ышану нияте белән, сак кына торып, тирә-якны карап чыга. Шатланып, кулларын угалый.* А.Гадел

**Шатлана башлау** Шатланырга тотыну. *Үзенең кылган хезмәтләренең файдасы, чиккән мәшәкатьләренең җимеше бик зур булачагына күңел ышанып шатлана башлады.* Г.Исхакый

**Шатлана төшү** Элеккегә караганда тагын да шатлану. *Урмановның взвод командиры итеп билгеләнүен белгәч, Верещагин тагын да шатлана төште ---.* Г.Әпсәләмов. *Атилла олан зәңгәр күк йөзенә карап алды, балалыгы белән Тәңрене күрмәк итте бугай, үзенчә киңәшеп алдымы, булган хәлләрдән тагы да шатлана төшеп: – Мин Тәңремне күрдем, күрдем, оста, ул миңа фатихасын бирде, бирде! – диде.* М.Хәбибуллин

**Шатланып җибәрү** Шатлана башлау. *Күңелне күтәреп җибәрдегез, кайтам да хатыннан сөенче алам, ул да шатланып җибәрсен.* Г.Камал

**Шатланып җитү** Кирәк хәтле, күңел булганчы шатлану. *[Фәтхия:] Балалар, атагыз Себердә... Аңардан һичбер хәбәр юк... Кайтуыгызга шатланып җитә алмадык... Инде сез дә китәсез!..* Г.Ибраһимов

**Шатланып йөрү** Соңгы вакытта, сөйләү моментында шатланган булу. *Мин ул вакытларда: «Бу ир-җегет миңа насыйп була икән», – дип шатланып йөргән идем.* Г.Ибраһимов. *Ә хуҗаларым, сизеп, миңа берни әйтми генә шатланып йөргән кебек тоелдылар.* Г.Галиева

**Шатланып китү** Берәр сәбәп чыгып кинәт кенә шатлану. *Красногвардеецтан нибары бер-ике чакрымда мул гына сулы елга ага иде. Гөлләр моны күргәч ачылып, шатланып китте.* Г.Әпсәләмов. *Кара әле, мин дә инде, адәм актыгы, шундый бәхет-сәгадәтне онытырга мөмкинме?! Үзем дә сизмәстән, шатланып китеп, йодрыгым белән өстәлгә суктым.* А.Хәлим

**Шатланып кую** Кинәт, көтелмәгән сәбәптән шатлану; азга гына шатлану. *Гөлбану --- малайга кинәт: – Җә, нәрсә торасың! Кузгал! – дип кычкырып җибәрде. Фәүзия килен борылып ук карады, шатланып куйды.* Г.Ибраһимов. *Бу рухи көчнең нигезендә ни генә ятмасын, авыр сугыш елларында янында шундый ышанычлы иптәше булуга Мирзаһит янә бер шатланып куя иде.* Г.Әпсәләмов

**Шатланып тору** Хәзер шатлану, шатлык хәле кичерү; даими, гел шатлану. *Көрәш мәйданында Гарифҗанны ансат кына алып ыргытуы, ат чаптыру вакытында аны икенче мәртәбә көлкегә калдыруы, шул хәлләрнең барысын да Мәрьямнең карап, үз күзләре белән күреп һәм шатланып торуы – болар һәммәсе дә Миңлебайның күз алдына кабаткабат килеп басты.* Н.Яһүдин. *Көннең матурлыгына сокланып, шатланып торган бер вакытта, кинәттән көчле җил чыкты ---.* Ф.Галәүтдинова

**ШАТЛАНЫП** *рәв.* Бик теләп, риза булып, шатлык, канәгатьлек хисе белән. *Мин бу эшкә шатланып риза булдым.* А.Алиш. *Әгәр минем белән хат алышырга теләсәң, шатланып язышыр идек.* А.Гыйләҗев

**ШАТЛАНЫШУ** *ф. урт. юн. к.* **шатлану**. *Алар, бер-берсен күрүгә, бертуганнар кебек шатланыштылар.* Г.Әпсәләмов. *Яшьләр, үз уеннарының уңышлы барып чыгуына шатланышып, кычкырып көләргә тотындылар.* Ф.Яруллин. *Яр буенда – яшел чирәмлек. Әбисе иртүк казларны шушында китерә. Казлар каңгылдаша, бәбкәләр пиппип дип, аларга кушыла. И сөенешәләр, шатланышалар инде!* С.Зыялы

**Шатланышып алу** Кыска гына вакыт эчендә шатланышу. *«Мин Чебенле авылыннан, монда укыйм», – дигәч, якын кешебезне күргәндәй шатланышып алдык.* Татарстан яшьләре

**Шатланышып кую** Кинәт, көтелмәгән сәбәптән шатланышу; азга гына шатланышу. *Шактый баргач, Равил: – Яуширмә утлары да күренде, тиздән барып җитәбез, кызлар, – диде, җанлана төшеп. Без дә шатланышып куйдык.* Ф.Тарханова. *Күп кенә җирләрендә исә үтеп китәрлек тар-тар сукмаклар калганын да күргәч, кяферләр шатланышып куйдылар.* Ф.Яхин

**Шатланышып тору** Хәзер шатланышу; даими, гел шатланышу. --- *бу ел арыш икмәге капмабыз, бодай гына ашап чыгарбыз, дип шатланышып тора идек, мал аңар да җитеп бара.* Г.Ибраһимов. *Ана белән улы шулай шатланышып торганда, аналарыннан Женя кайтты.* К.Тимбикова

**ШАТЛЫК** *и.* Шатлану, куану, канәгатьлек хисе; куаныч, сөенеч. *Үз гомеремдә мин беренче мәртәбә шундый матур иртә күрдем. Беренче мәртәбә, кешеләр өчен сөенеп, шатлык кичердем.* Н.Гыйматдинова. *Кызы, кияве белән күрешү шатлыгы Сания апаның бөтен йөзенә сибелгән иде ---.* А.Әхмәтгалиева

◊ **Шатлык чырае күрмим әгәр** Үзенең хаклыгына ышандыру өчен әйтелә торган ант сүзе. **Шатлык кабызу** Берәр юл белән кешенең кәефен, күңелен күтәреп җибәрү. *Һәм Эмманың нәни күңелендә Шатлык кабызырлар. Эмма өчен бүген көтмәгән Зур бәйрәм булыр.* М.Җәлил. **Шатлыктан кая басарга белмәү** Бик нык куанудан җилкенү, ашкыну. *–Балагыз булачак! – дигән хәбәрне ишетеп ---, шатлыктан кая басарга белмәгәндә, әнисе аны җиргә төшерә: – Балагыз булгач, нәрсә эшләрсез...* Сөембикә. **Шатлыгы эченә сыймау** Бик нык шатлану, куану. *Мондый хәбәрләр ишетелгәч, халыкның шатлыгы эченә сыймады.* М.Галәү. *Талияне күргәч, шатлыгы эченә сыймады Касыймның.* Г.Галиева

**ШАТЛЫ́К КЫЛУ** *ф. иск. к.* **шатлану**. *Хайваннар шатлык кыла уңдасулда.* Дәрдемәнд

**ШАТЛЫКЛЫ** *с.* 1) Шатлык китерә торган, шатландыра торган, сөенечле, яхшы, күңелле. *Бу шатлыклы хәбәрне ишетеп, әнисе бик сөенде, бүген иртәрәк кайтырмын дип вәгъдә бирде.* З.Хөснияр

2) Шатлык белән тулы, шатлыкны эченә алган. *Аның бүген бик шатлыклы көне, улы үз өенә кайткан көн иде, шаяртасы, көләсе, улы белән сөйләшәсе --- килә иде.* Н.Әхмәдиев

3) Шатлыгы булган, шатлык хисе кичерә торган. *Бу кызларның җырларын тыңлаганда, хәсрәтле кешеләр хәсрәтләрен оныткannар, шатлыклы кешеләрнең шатлыклары тагын да зуррак булып күренгән.* Г.Гали

4) Шатлык хисе белдергән, шатлыкны чагылдырган. *Якындагы текә таулар ягыннан, яшел урман өстеннән, төпсез күк бушлыгыннан – бөтен җирдән аңа нindидер шатлыклы көй, үзенә бертөрле күтәренке, гаҗәп көй ишетелә шикелле тоелды.* Н.Фәттах

**ШАТРАНҖ** *и. гар. иск. к.* **шахмат**. *Әмма нәрд вә шатранҗ уйнамакны гадәт итмә.* К.Насыйри. *Ярар, артык кыстап эчен пошырмыйк дигәндәй, хан якыннары кайсы шатранҗ уйнарга тотынды, кайсы нәрд шакмакларын таратты.* Р.Батулла

**ШАТРАЧ** *и. гар. иск. к.* **шахмат**. *Юлдан бабаем барды, Шатрач тактасы төшеп калды.* Табышмак

**ШАТРУН** *с. рус* Дүрт кыеклы пирамида формасында эшләнгән, дүрт кыеклы чатыр формасындагы. *Чишмә өстендә шатрун түбәле ике чатыр корылган.* А.Тимергалин. *Фатыйхларның шатрун түбәле зур агач өйләре әлеге тирән чокырның аргы ягында.* К.Миңлебаев

**ШАТТЛ** *и. ингл.* 1) Америка Кушма Штатларында төзелгән күп тапкыр кулланышлы космик транспорт корабле. *Әмма ул космоска очарга тиешле «Челленджер» шаттлы 1986 елда һәлакәткә очрый.* Әлмәт таңнары

2) Кыска араларда еш йөри торган транспорт (самолёт, автобус, поезд). *«Җиңү проспекты метро станциясе» тукталышыннан Үзәк мәдәният һәм ял паркына ипподром аша өстәмә шаттл йөреячәк*

**ШАТУН** I *и. рус техн.* Пешкәк белән двигательнең терсәкле валын тоташтыра торган деталь. – *Кара әнә,*

*тракторының янына барырлык та түгел, утлы мич кебек. Шуңа күрә, – дип дәвам итте бригадир, – балдакларны, шатуннарны карарга, фильтрларны, ягулык багын. – Аңлашылды, аңлашылды! – дип кычкырды Белугин.* Н.Фәттах. *Зиннур сул култык астына кыстырып торган шатуннарын җиргә ыргытты да, колачын җәеп, ничәмә еллар күрмәгән дустына таба атлады.* Сөембикә

**ШАТУН** II *и. рус* Кышка керер алдыннан вакытында өненә ята алмыйча калган яки өененнән өркетеп чыгарылган аю. *– Әнә күрәсезме, сопкага аю менеп киткән, – диде Вадим, Зуфирә янына килеп һәм мотор гөрелтесен басарга тырышканнан шактый кычкырып. – Хәзер өенендә ятарга тиеш ул. Берәр нәрсәдән өркеп уянган шатундыр, мөгаен...* М.Маликова

**ШАТУН** III *и. рус махс.* Атларда башның ми сүрүе ялкынсынуыннан гыйбарәт авыру. *– Шатун булса, Галәк бабай, ат дулый, алга омтыла, стенага үрмәли, бәргәләнә-суккалана.* Г.Әпсәләмов

**ШАТЫР** *иярт.* Әйбер сынганда, ярылганда яки ертылганда һ.б.ш. очракта чыккан тавышны белдерә. *Якында гына шатыр итеп агач сынды.* Безнең мирас

**ША́ТЫР-БОТЫР** *иярт. к.* **шатыр-шотыр**. *--- бу эшкә алар бик җиңел керештеләр: берсе шатыр-ботыр түбә шиферларын кубарды, икенчесе өй кыегы такталарына барып ябышты.* Ф.Яруллин. *--- авылдашым --- аш-су бүлмәсенә үтте, чәй куйганнан соң, шатыр-ботыр килеп, кичә калган шешә төбен эзли башлады.* А.Хәлим

**ШАТЫРДАГАН** *с.* Өр-яңа, киелмәгән. *Ифрат, шәп исле духилар сөртенеп, шатырдаган ефәк чапан, матур чалмадан килеп керә.* Ш.Камал

**ШАТЫРДАП** *рәв.* Бик нык итеп, каты итеп. *Күкрәгенә пуля тиеп Үтәли тишкән ие. Иреннәре күм-күк булган, Шатырдап кипкән ие.* Ә.Хәсәнов. *Тимераяклар итек табанына шатырдап ябышып каталар.* Ф.Сафиуллин

**ШАТЫРДАТУ** *ф.* Шатырдаган тавыш чыгару. *Кемнеңдер кайтмый калган сыеры агач-ботак шатырдатып йөри.* А.Гыйләҗев. *Күлмәкләрен шатырдатып ерта, күкрәкләрен ача.* А.Хәсәнов

**Шатырдата башлау** Шатырдатырга тотыну

**Шатырдатып алу** Кыска гына вакыт эчендә шатырдату

**Шатырдатып тору** Өзлексез яки әледән-әле шатырдату

**ШАТЫРДАТЫП** *рәв.* 1) Озын-озак уйлап тормастан, тоткарлыксыз; чатнатып, ачык итеп, тотлыгып тормыйча. *Аның өчен Нәсим җавап бирде: – Безнең Сафа маладис! – диде ул, егетне чын күңелдән мактап. – Урысчаны да, татарчаны да шатырдатып укый.* Н.Фәттах. *Җитәкчелеккә үрмәләү өчен, урысчаны шатырдатып белү, телең телгә йокмау, акцентсыз сөйләү төп шартлардан иде.* Т.Галиуллин

2) Каты, нык итеп, тоярлык итеп. *Таһир шунда өскә таба тырпаеп торган йөз егермеле кадакка шатырдатып китереп басмасынмы!* А.Хәсәнов. *Кызны шатырдатып кочаклый, үбә башлый, кыз каушап кала.* Р.Батулла

3) Каты итеп йолкып, бик тиз генә, җитез генә. *«Газиз катыны», үзенең корбанына килеп җиткәндә генә, мәчет коймасы буеннан шатырдатып умырып, бер көлтә кычыткан алды ---.* М.Мәһдиев. *Сәгыйтов өстәлдә яткан мәкаләсен шатырдатып тартып алды да каты басып чыгып китте.* Ф.Сафин

**ШАТЫРДА́У** *ф.* Берәр нәрсә шартлаганда, сынганда, ярылганда һ.б.ш. очракларда шатыр иткән тавыш чыгару. *Тун астындагы утын агачлары шатырдап уалды.* К.Насыйри. *Шатырдап күк ертыла, яшен уйный.* Ш.Галиев

◊ **Шатырдап торган** 1) Тотылмаган, таушалмаган. *Туйга шатырдап торган ике мең тәңкәне салдык.* Саба таңнары; 2) Бик каты, үзәккә үтәрлек. *Ләкин шатырдап торган салкын су да эче тулы ялкынны сүндерә алмады.* А.Вергазов; 3) Үтәли кипкән, бик коры. *Әмма шатырдап торган коры ботаклар төяп кайткач, әнинең рәхмәтен ишетү ни тора.* Ә.Хәсәнов

**Шатырдап алу** Кыска гына вакыт эчендә шатырдау. *Ишек артында нидер шатырдап алды*

**Шатырдап китү** Кинәт шатырдау. *Костаның сөякләре шатырдап китте, һәм ул, авыртуга түзә алмыйча, кыргый тавышлар чыгарып кычкырырга тотынды.* Р.Мирхәйдәров

**Шатырдап кую** Кыска вакыт арасында, бер тапкыр шатырдау. *Җилкә һәм терсәк буыннары сынар хәлгә җитеп, шатырдап куйдылар.* М.Юныс. *Он тагын да әйбәт тартыла башлый. Кинәт нәрсәдер шатырдап куя. Он урынына ниндидер ләпек нәмәрсә агарга керешә.* Р.Мирхәйдәров

**Шатырдап тору** Берөзлексез шатырдау; әле, хәзер шатырдау. *Инде агач яфракларына кадәр сап-сары утыра, аяк астындагы үлән шатырдап тора, кул тыгып булырлык җир ярыклары турында әйткән дә юк.* Безнең гәҗит

**Шатырдый башлау** Шатырдарга тотыну. *Бер-ике минуттан аның мотовелосипеды шатырдый башлады, аннары мотор гөрелтесе бик тиз ерагайды...* А.Тимергалин. *Елга уртасына җитә башлагач, аяк астында боз шатырдый башлаган.* З.Зәйнуллин

**ША́ТЫР-ПЫТЫР** *иярт. к.* **шатыр-шотыр**. *Кама ярына утырып шигырь язарга яхшыдыр, ләкин шау-шулы шатыр-пытыр шигырьләр түгел, күңелне иркәли торган, матур хисләр, матур мәхәббәт кузгата торган шигырьләр.* Г.Әпсәләмов

**ША́ТЫРТ-ШОТЫРТ** *иярт.* Өзек-өзек шатырдап куюны белдерә. *Агачлар арасыннан шатырт-шотырт Маһи әби килеп чыкты.* М.Гали

**ША́ТЫР-ШАТЫР** *иярт. к.* **шатыр-шотыр**. *Аякларындагы тимер богауны чак өстерәп, шатыр-шатыр зур ташлар тирәсендә кыймылдашалар.* Г.Ибраһимов. *Мәрхүмне соңгы юлга матәм маршы белән озаттылар. Җирләгәч тә, карабиннардан шатыр-шатыр атып, гимн уйнадылар.* Ә.Салах

**ША́ТЫР-ШОТЫР** *иярт.* 1) Берәр нәрсә шартлаганда, сынганда яки ватылганда һ.б.ш. очракларда барлыкка килеп, тоташ яки әледән-әле чыккан тавышны белдерә. *Шатыр-шотыр килеп, аллы-артлы куышып, моторлы көймәләр кайтты.* А.Гыйләҗев. *Кайдадыр шатыр-шотыр килеп ботаклар сынды, агачлар ауды ---.* Г.Сабитов. *Бот кимерә иде ире шатыр-шотыр, шулпа чөмерә иде хатыны шапыр-шопыр.* Ф.Яруллин

2) *к.* **шарт-шорт**. *Гариф агач башында шатыр-шотыр чикләвек [ярa].* Г.Тукай. *Бүген дә дошманнар күнегелгәнчә эшләделәр: шатыр-шотыр мылтык шартлатып --- кирегә борылдылар.* Р.Батулла

**ША́У** I *и.* **1.** 1) Бик күп төрле чыганаклардан ишетелгән, тәртипсез авазлардан кушылып барлыкка килгән тавыш. *Колак төбендә Рухия чишмәсе дә челтер-челтер итеп акмый икән хәзер, аны Кара диңгез шавы күмгән...* Н.Гыйматдинова. *Эт өрүеннән туктагач, каршыдагы урман шавы тагын да ачыграк булып ишетелде, тик тирә-*

*юньдә шуннан гайре тавыш-мазар колакка чалынмады.* З.Хөснияр

2) *к.* **шау-шу** (*2 мәгъ.*). *Ирләрнең җир өчен давы хатыннарның ир өчен шавы гына түгел икән.* Б.Камалов

3) *лингв.* Сөйләм органнарының ритмик булмаган тәртипсез тирбәнешләре нәтиҗәсендә һава агымының сөйләм аппаратында ышкылуы, шартлавы аркасында барлыкка килгән акустик эффект. *Акустик яктан сузык һәм тартык авазлар тон һәм шауның катнашу-катнашмавы белән аерылалар. Сузык авазлар, нигездә, бары тоннан гына торалар, ә тартыкларны әйткәндә, шау да катнаша.* Татар грамматикасы

**2.** *иярт. мәгъ.* Төрле тәртипсез авазлар кушылып барлыкка килгән көчле тавышны белдерә; гөр, гөж. *Без, үскән саен, вакытыбызның күп өлешен футболга бирәбез: ишегалды яки урам туп типкән малайлардан шау килеп тора.* Т.Кәримов

◊ **Шау итеп** *к.* **шау килеп**. *«Шура» шулай татар аңын дер селкетеп, баетып, уйларга, бәхәс итәргә, хыялланырга өйрәтеп, динне дә, сыйныфларны да сүкмичә, ләкин наданлыкка, фикер торгынлыгына каршы көрәшеп, тугыз ел буе шау итеп яшәп алды.* М.Мәһдиев. **Шау килеп** Шәп итеп, гөрләп. *Басуларда бодай уңсын шау килеп.* Ә.Ерикәй. **Шау килү** 1) Гөрләү, шау-шулы булу; 2) *к.* **шау кубу**. *Халык хәзер Кама Аланында төзелә торган атом электр станциясе турында шау килә.* Б.Рәхимова. *Бөтен урман халкы синең урман сараенда биюче җарияләрең бар дип шау киләләр.* А.Гадел. **Шау кубу** Нәрсәдән дә булса ризасызлык белдереп шаулый, гөж килә башлау. *Конферансье, тамашачылар алдына чыгып, Солтан әфәндедәнең авырып китүен әйтә һәм залдан гафу үтенә. Ләкин кая ул! Халык: «Чыксын, Солтан әфәнде чыксын!» – дип шау куба, конферансьега алдагы номерны әйтергә мөмкинлек бирми.* М.Мәһдиев. **Шау салу** Тавыш куптару, шаулау, гөж килү. *Башкалар: «Ул гына урлаган!» – дип шау салалар.* Ш.Маннур

**ША́У** II *кис.* **1.** 1) Бөтенләй, тулысынча, гел. *Тирә-ягы куе үлән, шау чәчәк, менә шул үлән-чәчәкләр эченнән бабакайның нечкә муены белән кырпу бүреге генә күренә.* Ә.Еники. *Болар килештергән: таныш түгел ирләр иңнәренә үзбәк халатлары киеп алганнар, билләрендә алтын-көмеш йөгертелгән хәнҗәр-кылыч, иярләренә тикле шау бизәктән иде.* В.Имамов

2) Саф, бернинди катнашмасыз. *Карасана шулпасына! Шау май гына.* Мәсәл. *Чыгарабыз шау алтын.* Н.Исәнбәт

**2.** *рәв. мәгъ.* Бик, нык, үтә, гаять. *Хуш ис аңкыткан калҗалар шау күмердә куырылганда телләр тик торамы?* А.Гыйләҗев. *– Нишлисең син, атасы? Нишлисең син, атасы, чәй шау кайнар бит! – диде Җомрия кыюсыз гына.* Р.Батулла

**ША́У-ГӨЖ** *и. к.* **шау-гөр**

**ШАУ-ГӨ́Ж КИЛҮ** *ф. к.* **шау-гөр килү**. *Без абыстайга барып кергәндә, кызлар шау-гөж килеп укып утыралар --- иде.* С.Батыршин. *Әле генә шау-гөж килеп торган вагон эче бер мизгелгә тынып калды.* Ш.Бикчурин

**ША́У-ГӨР** *и.* **1.** 1) Бик күп төрле чыганаклардан ишетелгән төрле авазлардан, тавышлардан кушылып барлыкка килгән гөрелте. *Тәрәзәдән карап, рәхәт уйлар кочагында тирбәлгәндә, Язкилдедә кош-корт шау-гөре башланды.* А.Гыйләҗев. *Өйдә шау-гөр, өйдә шат җыр, хәлләре бетәр көлеп.* А.Хәлим

2) *к.* **шау-шу**. *Фарукҗан, көндезге ыгы-зыгыдан, шау-гөрдән ял итеп яткан мәйданнар һәм урамнар буйлап елдам гына узып, Чархараска якынлашты.* Т.Әйди. *Тәнәфес вакытларында мәктәп ишегалды шау-гөргә күмелде.* Р.Мирхәйдәров

**2.** *иярт. мәгъ.* Төрле тавышлар, кычкырып сөйләшү, көлешү гөрелтесен белдерә. *Шау-гөр иткән тавыш ишетелеп тору*

**ШАУ-ГӨ́Р ИТҮ** *ф. к.* **шау-гөр килү**. *Аста, пәрдә артында, шау-гөр иткән тавыш, кызлар инде частушка сибәләр, бала-чага бүрек сугыш уйный иде.* М.Мәһдиев. *Шәһәрдән, күрше авыллардан килгән туган-тумачаларын, дус-ишләрен каршы аласы, үз төбәкләрендә шау-гөр итеп йөрисе килә аларның.* А.Вергазов

**ШАУ-ГӨ́Р КИЛҮ** *ф.* Шаулашу, тавышланып сөйләшү, көлешү. *Рамазан килеп төшкәндә, түгәрәк урман алдына җыелган халык шау-гөр килеп күңел ача иде инде.* Ф.Дәүләтбаев. *Шау-гөр килеп туйлар үтеп китте ---.* Х.Әбделмәнов

**ША́У-ГҮ** *и. к.* **шау-гөр**. *Зал тулы шау-гү эченнән бик тә таныш гөрләп көлү яңгырап китте.* Р.Төхфәтуллин

**ША́У ИТҮ** *ф.* 1) Шаулап тору. *Кастаньет сатучылар урамда көй чыгарып шау итәләр.* М.Мәһдиев. *Гомуми палатага күчер син аны, рәхәтләнеп эчен бушатсын, үзе ишеләр белән шау итсен.* А.Вергазов

2) Бер хәбәр нык таралу, бөтенесе шуны гына сөйләү, тавыш кузгалу. *--- гашыйк булдым, дип әйтеп кара, барча кызлар көлер. Алар гынамы, бөтен авыл шау итәр.* А.Вергазов. *Инде баланы тапкач та, Саматка Шакир кызын алып кайтып биргән, дип, бөтен авыл шау итә.* Г.Галиева

**ШАУКЫМ** *и.* 1) Кемнең дә булса эшчәнлегенең яки берәр вакыйганың һ.б.ш.ның тәэсире, йогынтысы, эзе. *Бикколның канында сәүдәгәр шаукымы бар иде.* М.Хәбибуллин. *Хатирәләр шаукымына бирелеп, өзеп-өзеп, ташлап-ташлап яза торгач, фикерләрне мәрҗән бөртеге итеп тезүдә дә өзеклекләр туа торгандыр инде.* А.Хәсәнов

2) Зарар, зыян. *Үзе төшеп калу бер хәл, шаукымы аның Андреевка да тиеп узды.* Ә.Еники. *Тәүге балаларыбыз туды да үлде, туды да үлде. Ызба иясенең шаукымы тиде.* Н.Гыйматдинова

3) Начар йогынты, вәсвәсә. *Болай да йоннары тырпайган Рәфиснең эчендә хыянәтчел көнчелек шаукымы кузгалды.* А.Вергазов. *– Сезнең авылның Әлмәттә яшәүче Әсгатьне сөйләгән идең, – диде Лениза, хәтәр усалланып. Хатыны бүтәннәр белән йөргәнен белгән дә асылынган. Авылыгызда шундый шаукым бармы?* Ф.Садриев

4) Көч, этәргеч. *Миңлегазиз карт белән булган шушы очрашу, шушы сөйләшү малайга шаукым булып килеп бәрелә, тетрәндерә, уйландыра, дала буйлап уктай очарга, юлындагы биек тауларга атылып менәргә этәрә.* Ф.Бәйрәмова

5) *миф.* Мифологик көчләр тудыра дип фараз ителә торган авыру, чир, сырхау. *Теләсәгез нәрсә әйтегез, шаукым дигән нәрсә ул өшкертмичә бетә торган түгел.* Ш.Камал. *--- кайсы гына якка атлама, барыбер юлга килеп чыгарга тиешсең, адашу һич мөмкин түгел. Ләкин башыңа зәхмәт шаукымы эләксә, ике нарат арасында да буталасың икән шул.* З.Мурсиев

◊ **Шаукым белән** Уйлап-нитеп тормастан, башкаларга кушылып; беренче тәэсиргә бирелеп, кинәт. *Андый зур эшкә шаукым белән генә керешмичә, ныклы хәзерлек белән тотынсак, әйбәтрәк булмас идеме.* Г.Ахунов. **Шаукым кагылу** 1) Мифик ышанулар нигезендә, җен, шайтан кебек ят көчләрдән

чир кагылу, төзәлмәс, дәвага бирелми торган авыруга дучар булу; зәхмәт кагылу. *Тегүче Җамалиның аягындагы коры сызлау тиз туктады. Мәрьямбикәләрнең, Сиражиларның шаукымы кагылудан гына башланган ул чир шулай ук тиз бетеп китте.* Г.Ибраһимов. *Әллә син дә җенләндеңме?.. Бу ни бу, боларның барысына да җен шаукымы кагылган. Тәүбә... тәүбә... Суфидан тәлинкә яздырып эч!..* К.Тинчурин; 2) Нәрсә белән дә булса мавыгу, шуңа тулысынча бирелү. *Үзләре иҗат итмәсәләр дә, әдәбият шаукымы кагылган кешеләр бар.* Ш.Галиев. *Маратка аквалангистлык шаукымы кагылган иде. Яз башыннан бирле инде ул, мылтык алып бир, дип, Латифның колак итен ашады.* А.Расих. **Шаукым сугып йөрү** Кемнәрнеңдер арасын бозып, үзара талаштырып, дошманлаштырып йөрү; шомлык таратып, фетнә чыгарып йөрү

**ШАУКЫМЛАНУ** *ф.* Нәрсәнең дә булса тәэсиренә бирелү; шаукымы, зарары тию. *Снарядның башы гына аның җилкәсенә тигән, ул шуннан аз гына шаукымланган.* А.Таһиров. *Өстенлек үзләрендә калудан шаукымланган бер төркем аларны таштыр, кантардыр атып, авыл башына кадәр эзәрлекләп барды.* Т.Нәбиуллин

**Шаукымлана бару** Торган саен ныграк шаукымлану. *Аның кайнар хиссият белән сугарылган сүзләреннән Рәгыйбь торган саен әсәрләнә, шаукымлана барды.* А.Хәлим

**Шаукымланып йөрү** Әле, хәзер, бөтен җирдә шаукымлану. *Яшь чакта була инде ул. --- Элек тә яшьләр шулай хикмәт чыгарып куялар иде. Әхмәтсафа да бу шаукымланып йөргән ташлар...* Ф.Сафин

**ШАУКЫМЛЫ** *с.* 1) Начар йогынтысы булган, начар тәэсир итә торган. *Белгән догаларымны укый-укый, бу шаукымлы урыннан тынычрак почмакка күчәсе иттем.* Ш.Маннапов. *Өн белән төш арасында буталган кара дәҗҗал, ни Һашия, ни кош, аның канын суыра иде. Нигезе шаукымлы, ахрысы, юньле кеше ярым ташландык урыс авылында бура күтәрәмени?!* Н.Гыйматдинова

2) Тынычсыз; шомлы, хәвефле, тәшвишле. *Шаукымлы, буталчык, ата улны, ана кызны беләсе түгел көннәр.* З.Нури. *Бу шаукымлы елларда Тукай иҗатын халыкка җиткерү һәм аны «буржуаз милек»кә әйләнүдән саклап калучыларның иң күренеклесе, иң зур хезмәт куючысы, әлбәттә, Фәтхи Бурнаш була.* Д.Абдуллина

3) Акылсыз, уйламыйча эш итүчән, кызу канлы, дуамал. *Бөтен авыл халкын хәйран калдырып, Рәйхан уйламаганда-көтмәгәндә шаукымлы, иләсмиләс диган даны чыккан Фаягөл малае Габделхаккка кияүгә чыкты.* Д.Каюмова

**ШАУЛАП** *рәв.* Шәп, бик яхшы итеп, гөрләп. *Тиздән шаулап яфрак ярыр Озын ак каен.* Ф.Кәрим. --- *июль башлары, дөньяның хуш исле хәтфәгә уралып, игеннәрнең шаулап үсеп утырган чагы иде.* В.Нуруллин

**ШАУЛАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **шаулау 1**. *Габәши һәм Әлмөхәммәтовларның беренче хезмәте булган «Сания» операсы турында хәбәр бөтендөнья матбугатын шаулата.* М.Мәһдиев. *Тышта кар бураны улый, агач башларын шаулата.* З.Зәйнуллин

2) Шау-шуга күмү, тавыш чыгару, тавышлану. *Урам ашханәсенең граммофоны бөтен базарны шаулата...* Г.Бәширов. *Бераздан гына шаулатып кул чабарга тотындылар.* Г.Галиева. *Бераз читкәрәк киткәч тә, сакланып та тормастан, бөтен елганы шаулатып, моторларын эшләтә башладылар һәм өерләре белән уң як ярдагы тауларга таба юнәлделәр.* С.Сабиров

**Шаулата башлау** Шаулатырга тотыну. *Җитәр инде, Хөснетдин абый, колакларымны шаулата башладың.* Ш.Камал

**Шаулатып алу** Бераз, аз гына вакыт шаулату, бер тапкыр шаулату. *Җилләр генә бер шаулатып ала Урманнарын минем күңелнең.* Ф.Яруллин. *Кайтуга, «Сак-Сок» бәетен югары сәнгать әсәренә әверелдереп, Казанны бер шаулатып ала.* Сөембикә

**Шаулатып җибәрү** Кинәт шаулата башлау. *Кинәт искән җил ул агачларның яфракларын дәррәү генә шаулатып җибәрә ---.* Ф.Яхин. – *Килен килә!* – *дигән тавышлар әйләнә-тирәне шаулатып җибәрде.* Н.Яһудин

**Шаулатып йөрү** Шактый вакыт, күптәннән, бертуктаусыз шаулату. *Дөньяны шаулатып йөргән Хәйриянең шул сәер төшне күргәннән бирле тынычлап йоклаганы юк.* М.Хуҗин. *Без, бала-чагалар, төркем-төркем иртәдән кичкә кадәрле урам шаулатып йөрибез.* Туганайлар

**Шаулатып кую** *к.* **шаулатып алу**. *Ләкин зур өметләр белән шаулатып куйган халтурасы бертөрле дә җиңеллек китермәде.* Ә.Еники

**Шаулатып тору** Әле, хәзерге вакытта шаулату; өзлексез яки әледән-әле шаулату. --- *бөтен абзар-кураларны, алай гына да түгел, бөтен ишегалдын шаулатып торган бу сыер саву тавышы, туктаусыз гөжләгән бу сөт агымы бөтен йортка ямь бирә --- иде.* Г.Галиев. *Кич белән яшьләр гармуннар уйнап, җырлап, авылны шаулатып торалар иде.* Ф.Галиев

**ШАУЛАТЫП** *рәв.* 1) Шәп, яхшы итеп; зурдан кубып. --- *кызым икенчегә кияүгә чыга. Беренче туен акча җәлләп, ни ылтара, ни пылтара гына ясаган идем – тормадылар. Монысын гөрләтеп, шаулатып, затлы ресторанда уздырмасам, исемем Әсмабикә булмасын.* Т.Галиуллин

2) Чатнатып, шартлатып, тотлыкмый. --- *география, әгәр карта янындагы кеше шаулатып сөйләп бирмәсә, кәефе китеп тәрәзә янына килеп баса да --- басуга карап тик тора.* М.Мәһдиев. *Солтанхәким --- кечкенәдән гыйлемгә хирыс булды, ун яшендә шаулатып Коръән укый иде, намазын калдырмады.* Ф.Бәйрәмова

**ШАУЛА́У** *ф.* 1) Берничә кеше берберсен тыңламыйча берьюлы кычкырып сөйләү, гөжләү, гөрләү. *Әллә нинди күз күрмәгән, колак ишетмәгән товарлар белән тулган кибетләрнең алдында, умарта корты кебек, халык шаулый ---.* Г.Ибраһимов. --- *уенчыклар беткән чакта, кибет тынган. Балалар да шаугөр килеп шауламаган, тегене ал да моны ал дип, һичбер бала әнкәсеннән уенчыклар дауламаган.* М.Мәһдиев

2) Кешеләр яки башка тереклек ияләре тавышыннан билгеле бер урын гөжләп, шау-гөр килеп тору. *Мәйдан шаулый, районнар ярминкә оештырган: эремчек, каймак, черегән бәрәңге һәм тагын әллә нинди исләр борынны яра ---.* Н.Гыйматдинова. *Клуб шаулый, гөрли.* А.Хәмзин

3) Хәрәкәттәге техника, эшләп торган механизмнар тоташ шау, гөжләү, гөрелте чыгару. *Печатник машинаны ходка җибәрә, машина шаулый, гөрли.* Г.Исхакый. *Киң бетон юлларга бер-бер артлы самолётлар куна башлады. Моторлар шаулады ---.* А.Гыйләҗев

4) Тигез тавыш чыгарып гөжләү. *Почмак якта ишетелер-ишетелмәс моңсу гына бер көйгә самавыр шаулап утыра.* Г.Бәширов. *Морҗалардан күккә төтен аша, Җиз самавыр шаулый һәр өйдә.* Ф.Ибраһимов

5) Кайнау; быгырдап, күбекләр чыгарып, көчле кайнап утыру. *Шәмсия әллә кайчан аяк өстендә икән шул, казанда су шаулый, комганга җылы су салынган ---.* Ф.Сафин. *Кырык чиләк су сыйсын, Ишегалдында булсын, Су шаулап кайнап торсын.* Х.Җәләй

6) Ургылып, ярсып агу. *Сәлим әйтә ди, мин аның аркасына өч кадаклы гер белән бирдем, дип әйтеп әйтә ди, шуннан соң танавыннан шаулап кан китте, дип мактана ди.* М.Гафури. *Өске катка күтәрелмәсәләр дә, пароходның кызыклы урыннары болай да күп икән. Түбәндә, аларның аяк астында гына су шаулый, сикереп кайнап тора.* М.Хәсәнов

7) Кою, күп итеп, көчле һәм өзлексез яву. *Төш вакыты җитәрәк, яңгыр тагын да көчәйде: йортларның түбә, тәрәзә калайларына шыбырдап, агач башларын түбән идереп, чиләкләп койган кебек шаулап ява башлады.* Р.Кәрами

8) Җилдән чайкалып яисә үзара бәрелешеп тавыш чыгару. *Диңгездә өермә. Дулкыннар шаулый.* М.Җәлил. *Шомландырып, урман шаулый.* Р.Мөхәммәдиев. *Җилләр белән тук башаклар шаулый Иксез-чиксез иркен кырларда.* Р.Зарипов

9) Уйлар киеренкелегеннән, ару, авыру яки башка сәбәпләрдән тавыш, шау тою. *Фәхерниса карчык урынынн тора, «юк шул, бәпкәм, юк» дип авыр сулый, кемдер йөрәккә салкын су коя, йөрәк туктагандай итә, баш шаулый...* М.Мәһдиев. *Элек валидол да булыша иде, хәзер әллә нинди көчле дарулар да тәэсир итми. Көн дә кан басымы, көн дә колак шаулый.* З.Мәхмүди

10) *юкл. форм.* **шауламау**. Эчтән тыну, берәүгә дә әйтмәү, берәүгә дә сиздермәү, сер итеп саклау. *Аракы алай бик күп түгел, кибеткә чыгарып тормасаң да була иде. Шуңа күрә, ачыктан-ачык сату-сатмау мәсьәләсен хәл иткәнче, хәзергә бу турыда теләсә кемгә шауламаска булдылар.* Н.Фәттах. *– Кибәк баш, – диде әлеге егет, – бу кәгазьнең бәясе бер матчалык кына түгел. Беләсең килсә, моның белән паспорт алырга була. Тик шауламаска гына кирәк.* Ф.Яруллин

11) *куч.* Берәр эшкә ризасызлык белдереп тавыш күтәрү; даулау, берәр нәрсә таләп итү. *Җыелыш кызды, гөрләде, шаулады, нинди генә исемнәр аталмады ---.* Н.Гыйматдинова. *Полковник озак шаулады һәм, ниһаять, пары чыгып беткәч, мондый йомгак ясады: – Офицерлар! – диде ул, барысына да карап чыккач, – безнең частьта мондый хәлнең булганы юк иде әле.* И.Хуҗин

12) *куч.* Нинди дә булса бер вакыйганы күтәреп алу, бары тик шул турыда гына сөйләү. *Егерменче еллар матбугаты Г.Газиз һәм Г.Рәхимнең ул хезмәтләре турында күп шаулады, күптөрле фикерләр әйтелде.* М.Мәһдиев. *Әлеге вакыйгадан соң ике айлап вакыт уздымы икән, Михайлов кабат көн героена әверелде. Бу юлы артиллеристлар дивизионы гына түгел, бөтен крейсер шаулады.* Н.Әхмәдиев

13) *куч.* Дан таралу, халык телендә булу, исеме чыгу, танылу. *--- исемнәре күптән инде дивизиядә генә түгел, бөтен һава армиясенә билгеле. Аларның батырлыгы бөтен фронтка шаулады.* Казан утлары

◊ **Шаулап торган** Нык үсеш алган, алга киткән, чәчәк ату чорында булган. *Башкалар Нариман исемендәге совхоз, аның кайчандыр шаулап торган бистәсе булганлыгын белми дә.* Т.Нәҗмиев. *Шаулап торган зур калалар белән чагыштырганда, Саклык сыман җыйнак авыллар сабый бала гына кебек.* Р.Габделхакова

**Шаулап алу** Аз гына, берара шаулау. *Буферлар шаулап алды.* М.Мәһдиев. *Капыл гына урман шаулап алды, тегендә-монда мамыктай кар бөртекләре очты, агач башлары җилдә чайкалды.* С.Шәрипов

**Шаулап йөрү** Соңгы вакытта бертуктаусыз шаулау. *Күктән түбәнгә төшә башлаган кошлар, --- нишләргә белмичә аптырап, бик озак шаулап йөрделәр ---.* Ч.Айтматов. *Тик аскы этаждагы хатын гына: «Барыбер сүттереп ыргытам мин аны, балкон төбенә үк китереп куйдыгыз», – дип шаулап йөри.* Ф.Яруллин

**Шаулап калу** Шауларга өлгерү; шаулавын дәвам итү. *Сабан туе элеккечә шаулап калды, әткәй күп баһадирларны җиңеп алган кызыл башлы сөлгеләр белән яшел чапанны бер як кулбашына салды да --- акрын гына кайтып китте.* Г.Ибраһимов. *--- артта, беркемгә, бернәрсәгә колак салмыйча, мәңге хәрәкәттә яткан ташкын дәрья шаулап калды.* Н.Фәттах

**Шаулап карау** Булдыра алу-алмавын сынау, тикшерү өчен шаулау. *Берничә кеше килеп шаулап карый, ләкин аларны дружинниклар кертмичә куып җибәрә.* Р.Батулла. *Бабай, шаулап кара, Чыбык белән яра. Менә әйбәт чара – Шәрәф шәрран яра.* Р.Миңнуллин

**Шаулап китү** Кинәт шаулый башлау. *Пуляларның берсе, каскасына тиеп, чыңлап үтте. Газинурның башы шаулап китте.* Г.Әпсәләмов. *Менә шунда инде, караңгы төшеп килгәндә, чиләкләр тавышы ишетелде. Булат бәкнең колагы шаулап китте, йөрәгә колак төбендә үк дөп-дөп тибә башлады.* М.Хәбибуллин

**Шаулап кую** Бер тапкыр, кыска гына вакыт шаулау. *Яңадан ура тавышы яңгырады. Урман, җавап кайтаргандай, шаулап куйды.* Г.Әпсәләмов. *Шомлы җилдә шаулап куйды әрем ---.* Р.Әхмәтҗан

**Шаулап тору** Әле, хәзерге вакытта шаулау; бертуктаусыз шаулау. *Гәрәбәдәй сары кәүсәле, иртә-кич берөзлексез шаулап торган мәһабәт наратлар --- Газинурның йөрәгенә кереп урнаштылар ---.* Г.Әпсәләмов. *Биек зал алкышлар белән шаулап торды.* Х.Камалов

**Шаулый башлау** Шауларга тотыну. *Шәфикъ тавышын ишетеп, тыштагы халык та гөжләп шаулый башлады.* М.Галәү. *Гәрәй --- әле рәтләп урнашырга да өлгермәгән иде, тышкы якта пароход көпчәкләре шаулый башлады ---.* С.Сабиров

**Шаулый тору** Шаулауны дәвам итү. *Оранчы хан сүзләрен кычкыра торды, халык шаулый торды.* М.Хәбибуллин. *Аннары, шаулый торсын, дип, миңа чәй куеп килергә кушты.* М.Садыйков

**ШАУЛАШ** *и.* Шаулашкан тавышлар; шау-гөр. *Бүлмәдә гомуми сөйләш, шаулаш, көлеш.* Ф.Әмирхан. *[Әби], Ләләнең каршына барып, иркәләп, көлдереп төрле картиналар бирә. Көлеш, шаулаш.* М.Фәйзи

**ШАУЛАШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **шаулау**. *Тышта аязды, атналар буе лапас астында тилмереп яткан председатель казлары биек нарат капка янына килеп өелгәннәр, иркенгә чыгасылары килеп шаулашалар.* М.Мәһдиев. *Саргайган үләннәр җиңелчә шаулашалар.* А.Расих. *Карт эрбет, нарат агачларының түбәннән генә йөзгән болытларга терәлгән ябалдашлары җан өшеткеч авазлар чыгарып шаулашалар.* М.Хәсәнов

2) Үзара кычкырышу, талашу, әрләшү. *[Бәдигылҗамал Зәйнәпкә:] Ни эшкә шаулаштыгыз, ни эшкә бозылыштыгыз, әллә берәр хәл булганмы?* Г.Камал. *Ә без – Илһамия апаның агач*

*таягына буйсынырга өйрәтелгән юеш борыннар – дилбегә бушаганны сизгән тук ат төсле тәртипсезләнә, шаулаша, сугыша ук башлыйбыз.* Т.Галиуллин

**Шаулаша башлау** Шаулашырга тотыну. *Каты җил өй түбәсе саламнарын тузгытты, тирәкләр, яшь ботакларын җиргә чаклы иеп, зарланышкан сыман шаулаша башладылар*. М.Галәү. *Халык бик гаҗәпләнде, нәрсә әйтергә белмичә шаулаша башлады.* М.Гали

**Шаулаша тору** Озак шаулашу; башка эш-хәрәкәтләр белән бер вакытта шаулашу. *Әнә Казанда тагын йөз елга чыдарлык тарихи биналарыгызны җимереп, ут төртеп, алар урынына йорт төзи байлар. Халык шаулаша тора, болар төзи тора.* Н.Гыйматдинова

**Шаулашып алу** Кыска гына вакыт арасында, бераз шаулашу. *Шулай үткәзеп җырлаганнан соң, кунаклар бер шаулашып алалар: – Һай, ирләрнең асыллары!* Ә.Еники. *Юлчылар тарлавыкның икенче ягына якынлаштылар һәм, сөенеч тойгысына бирелеп, җиңелчә шаулашып алдылар.* Н.Фәттах

**Шаулашып карау** Булдыра алуалмавын сынау, тикшерү өчен шаулашу. *Эшчеләр шаулашып карадылар, әмма хуҗаның нык карарлы йөзе таш, күзләре пыяла сыман үзгәрешсез калды.* Ә.Фәйзи. *Без бу хакта митингка чыгып --- шаулашып карадык инде*. Татарстан яшьләре

**Шаулашып кую** Кинәт кенә шаулашу, бер тапкыр шаулашу. *Җил исеп китте, агач башлары шаулашып куйдылар*. Г.Гобәй. *Партком члennары ризасызлык белдереп шаулашып куйдылар: – Кисәтү бик җиткән инде.* Ф.Садриев

**Шаулашып тору** Әле, хәзерге вакытта шаулашу; даими, әледән-әле, һәрвакыт шаулашу. *Инде ике як та кызыпчынлап бер-берсенә каршы баскан, хәнҗәр сапларын учка сеңдереп, күз тондырып, яман сүзләр чәчеп, беркавым шаулашып торганнар.* С.Сабиров. *Сатып алучыларның дистәгә якын туганнары, танышлары җыелып өлгергәннәр. Шаулашып торалар.* Т.Галиуллин

**ШАУЛЫ** *с.* 1) Тавышлы, шаулый торган. *Апалары исә зур шаулы калада, дөбердәп колакларны саңгыраулаткан таш урам буйлап каядыр бара*. Ә.Баян. *Иксез-чиксез диңгез эчендә, шаулы дулкыннар арасында Фәнияр үзенең авыру икәнлеген онытты*. Ф.Яруллин

2) Шау-шулы, зур, әһәмиятле вакыйгаларга бай булган. *Белеме дүрт сыйныфтан ары узмаган, ләкин шаулы елларда ул үз авылының, үз чорының иң алдынгы, иң актив яшьләреннән исәпләнелгән*. Н.Фәттах. *Шул шаулы көннәрдә нинди генә вакыйгаларга очрамады ул.* Т.Әйди

3) *лингв*. Акустик яктан бары тик шаудан яки башлыча шаудан торган. *Шаулы тартыкларны әйткәндә, шау тонга караганда күбрәк катнаша яки алар бары шаудан гына да торырга мөмкин.* Татар грамматикасы

**ШАУ-ШУ** *җый. и.* 1) Тавыш; тоташ көлеш-кычкырыш. *Ләкин инде шуны беләм: ялгызлык сагышын дискотекалар шау-шуы күмә, җиңә алмый ---.* Ә.Баян. *Шүрәле бабай, балалар арасында шау-шуны ишетеп, ярдәмгә килде: – Сез кино төшерүнең серләрен белмисез ахры, балалар*. Л.Янсуар

2) Гауга, ызгыш-талаш, җәнҗал, кычкырыш. *Редактор вакытында ук Сабитов беркемне дә санга сукмады. Шуның аркасында газетада нинди генә материаллар чыкмады, нинди генә шау-шулар купмады*. Ф.Садриев. *Уракка төшкән көннәр булуга карамастан, авылларда шау-шулар башлана. Сәнәкчалгы күтәргән халык авыл мәйданнарына җыела.* Л.Хәмидуллин

3) Бәхәс, моназара. *Үзенең халык арасында никадәрле шикләнүләр, куркуөркү, шау-шу китереп тудырганын үзе үк күреп, ишетеп торадыр бит инде югыйсә.* Р.Фәизов. *Капка төбендә, бик кызу гына бер-берсен этешә-төртешә, дүрт-биш карт гәпләшә иде. Каршы яктан капканы урамдагы әлеге шаушуга борчылган әтисе үзенә тартты.* Г.Нурулла

4) Ыгы-зыгы, мәшәкать. *Мансур өчен, мәсәлән, бу минутта тамчылар тамуы гына түгел, зур дөнья үзе дә, аның шау-шуы да, кайгысы-шатлыгы да, хәтта кешеләре дә юк иде*. Г.Әпсәләмов. *Метролар юк синдә, трамвайлар юк, Ыгы-зыгылар юк, шау-шулар. Нинди тыныч әкияти шәһәр!* Р.Миңнуллин

◊ **Шау-шу килү** Шаулашу, тавышлану, гөр килү, гөж килү. *Без, ялланырга килүче көнлекчеләр, шау-шу килеп этешә-төртешә, бөтенебез бердәй аның ягына чыгып беттек*. Г.Бәширов. *Бу көтелмәгән әмердән каушап калган вагон бермәл тынсыз торды да аннары шау-шу килеп уяна, җанлана башлады.* З.Хөснияр. **Шау-шу кузгату** *к.* **шау-шу күтәрү**. *Кайберләре инде атна-ун көн тикшерелмичә, чират көтеп тора, бу кандала оясында озак тотудан зарланып, шау-шу кузгаталар.* С.Сабиров. *Спектакль үзе дә шау-шу кузгатып узды.* Ә.Баян. **Шау-шу куптару** *к.* **шаушу күтәрү**. *Нишләтәсең, дустым, нәкъ менә иҗатта сай йөзүчеләр үз исеме тирәсендә шау-шу куптара, мактаулар оештыра.* Н.Гыйматдинова. *Зур резонанс тудырды әлеге чыгыш, фәнни даирәләрдә шау-шу куптарды.* Ә.Эминев. **Шау-шу күтәрү** Бәхәс башлау, дау, ызгыш кузгату. *Төзелеш, димәк, синең өчен бер трамплин гына. Син монда партиягә кандидат булып кереп, шаушу күтәреп, августта китеп барсаң, беләсеңме, синең турыңда нәрсә дип әйтәчәкләр?* М.Мәһдиев. *Шуңадырмы чиксез ашыгабыз, Шау-шу күтәрәбез чамасыз. Бабайлардан калган сабырлыкны, Түземлекне онытып барабыз.* Р.Гатауллин

**ШАУ-ШУЛАНУ** *ф.* Шау-шу күтәрелү, шау-шуга күмелү. *Өй эче шаушулана, тыгызлана, бөркүләнә.* А.Шамов. *Өй эче җанланып, шау-шуланып, кызыклыланыбрак китте.* Г.Иделле

**ШАУ-ШУЛА́У** *ф.* Шаулау, шау-шу килү. *Котлары очкан мәләкләр шаушулап Алдылар Җибрилне сөенеп каршылап.* Ш.Бабич. *Март-матур үтеп китте шау-шулап.* Г.Хәсәнов

**ШАУ-ШУЛЫ** *с.* 1) Тавышлы, шаулап торган, гөж килеп торган. *Яр өстендәге куе талтирәк арасыннан гармун тавышы, кычкырып көлүләр ачык ишетелә, шау-шулы җанлылык көчәйгәннән-көчәя бара.* С.Сабиров. *Аяк өсте капкалап алырга кергән юлчылар, ялгыз башы салып утырган бер-ике сәрхуш һәм шау-шулы яшьләр төркеменнән башка берәү дә күренми.* Л.Ихсанова

2) Ыгы-зыгылы, мәшәкатьле, борчулы, тынгысыз. *Кеше һәрвакыт шәһәрнең шау-шулы, ыгы-зыгылы тынгысыз тормышы эчендә әйләнә, аның чын-чыннан үзе һәм башкалар турында уйларга да, тормышның үзен күрергә дә вакыты юк ---.* Г.Бәширов. *Аның шау-шулы тормышы мине дә өермәдә бөтереп, үз эченә алып кереп китте.* Г.Галиев

**ШАУ-ШУСЫЗ** *рәв.* **1.** 1) Тавышсызтынсыз, бернинди шау-шу чыгармыйча. *Өлкәннәрдән читтәрәк, күләгәле якта торган яраннар бернинди шаушусыз, шулай да бик җитез кыланып, ашаучылар алдына калын чыпталар --- куеп чыктылар.* Н.Фәттах. *Ак әби шау-шусыз, тыныч кына керде дә, Булатның аяк очына утырып, дога кыл-

*ды, аннары шулай тавыш-тынсыз гына чыгып та китте.* Г.Гыйльманов

2) Тыныч кына, беркемгә дә сиздермичә, мыштым гына

3) Шаулашмыйча, гауга-җәнҗалсыз гына. *Шау-шусыз, гади генә узган тормышта да әллә никадәр соклангыч вакыйгалар, кабатланмастай күңелле хәлләр, онытылмаслык истәлекләр була.* Г.Әпсәләмов. *Туй бернинди шау-шусыз билгеләнгән көнне, билгеләнгән сәгатьтә башланып китте.* Р.Мөхәммәдиев

4) Бәхәссез, каршылыксыз, җайлы гына. *Доклад шулай тыныч кына, шау-шусыз үтәр кебек иде, ләкин тыныч кына бетмәде.* А.Шамов. *Искәндәровның чыгышын тын да алмый тыңладылар, яңа рәисне шау-шусыз гына бертавыштан сайлап та куйдылар.* М.Маликова

**2.** *с. мәгъ.* 1) Тавыш-тынсыз. *Даими һәйбәт тукланырга, --- борчылмаска, кайгырмаска, кабаланмаска, ярсымаска, үз вакытында шау-шусыз урында йокларга, вакытында торырга, режимны бозмаска!* А.Гыйләҗев. *Операция шау-шусыз, атышсыз, кансыз булырга охшап тора.* В.Нуриев

2) Тыныч, һәртөрле гаугасыз, тигез, салмак. *Бер балчык өйдә чабатачы Шәмси бабай белән җон эрләүче Гайни карчык үзләренең һаман бер төсле, һаман тыныч, шау-шусыз гомерләрен үткәрә булганнар.* Г.Ибраһимов. *Авылда ул тыныч, шау-шусыз көннәр кичерде.* Ф.Садриев. *Вакыты-вакыты белән бик моңсу да була иде. Шулай да шау-шусыз, тавыш-тынсыз тормышка ияләшкән, күнеккәннәр иде инде.* Безнең мирас

**ШАФРАН** *и. фар.* 1) *к.* **зәгъфран**. *Аяк асты гүя йомшак ап-ак шафран, Яфракларны, очмасын дип, ак кар япкан.* Р.Әхмәтҗан. *Чәчәк аткан сары шафраннар шәһәребез үзәгенә ямь кертте, урамнан узганда алар күңелне, күзләрне иркәли.* Әгерҗе хәбәрләре

2) Баллы алма сорты; шундый сортлы алма. *«Шигырь темасымыни Сөтләр, итләр, силослар? Шомыртны яз, шафранны» Диләр дә бит чын дуслар.* Х.Туфан. *Үсә аркад, үсә шафраны. Күләгәләп җирне, агачларның Шаулый җирдә куе яфрагы.* С.Хәким

**ШАХ** *и. фар. к.* **шаһ**. *Булат җәяүлене кучерде дә партнёрының мие капланудан файдаланып, икенче йөрештә үзенең турасы белән тегенең атын алып ташлады, ә корольгә шах игълан кылды.* Г.Ибраһимов

**ША́ХЕР-МАХЕР** *и. нем. гади с. к.* **шахыр-махыр**. *Старостага нәрсә? Шахер-махер. Мондый эшкә [немец сәүдәгәре өчен урман кистерүгә] бик тә каһәгать.* Ш.Мөдәррис

**ША́ХМАТ** *и. фар.* 1) Aклы-каралы 64 шакмаклы тактадан һәм төрле формадагы уналтышар ак һәм кара төстәге фигурадан торган уен комплекты; шатранҗ. *Иптәшләремнең әйтүләренә караганда, аның һәр иртә-кич шахмат тактасына карап уйлана-уйлана җырлый торган җыры шагыйрь Тукайдан алынган.* Г.Кутуй. *Ачудан, коньяк алып, аның номерына мендек, буфеттан коры-сары ашап, кузгалган нервларны басар өчен, шахмат уйнарга тотындык.* В.Нуруллин // Әлеге фигураларның үзе. *– Лей... те... нант, борынгы акыл ияләре уенын бер тет... тереп алыйк әле, – ди ул, һәр сүзне бик зур авырлык белән әйтә-әйтә --- шахматларны тезеп куя.* Г.Әпсәләмов. *Мәхмүт ипидән бик матур итеп шахмат сыннары эшләде.* И.Салахов

2) Кара-каршы шундый фигураларны такта өстендә билгеле кагыйдәләр нигезендә күчереп йөртеп, отарга тырышуга корылган логик уен. *Нindidер отышлы йөреш алдыннан берәр сәгатькә тирән уйларга чумып утырган шахмат осталарын күп тапкырлар күргәнем булды. Бу затлы уенны үзем дә бик яратам, күп еллар рәттән шахмат клубына йөрим.* А.Хәсәнов. *Беренче класста укыганда ук, шахмат уйнарга өйрәндем ---.* Н.Әхмәдиев

◊ **Шахмат тәртибе белән** *к.* **шахмат тәртибендә**. **Шахмат тәртибендә** Нинди дә булса әйберләрнең ике яки аннан артык рәт булып, шахмат тактасындагы шакмаклар тәртибенә охшатып, чиратлашып урнашуы турында. *Шушы ясалма күн пәрдә шахмат тәртибендә тип-тигез итеп үткен пәке белән кискәләнгән иде.* А.Тимергалин. *Биналар төзек, шахмат тәртибендә тезелгән йөзем казыклары басуларга аерым бер пөхтәлек өстәгән.* Т.Әйди

**ША́ХМАТЛЫ** *и. к.* **шахмат** (*2 мәгъ.*). *Шахматлы уйнарга дип хыялланып утырам.* Ә.Баян. *Мин клубка килеп керсәм, шахматлы уйнап утыручы җегетләр, аягүрә басып: – Уйныйсыңмы? – дип сорый.* Р.Батулла

**ША́ХМАТЧЫ** *и.* Шахмат уены спортчысы; гомумән, шахмат уйнаучы кеше. *Атаклы шахматчы Нәҗметдинов белән кайчандыр бер ничьяга уйнаганын инде йөзенче тапкыр мактана-мактана, уйныйк инде дип, инәлеп сорагач, Уразиков каршы килә алмады...* М.Галиев

**ША́ХТА** *и. нем.* 1) Файдалы казылмаларны җир астыннан чыгару, казылмаларны баету комбинатына яки кулланучыга төяп озату эшен алып барган тау сәнәгате предприятиесе. *Шахтага китү, җир астына төшеп күмер чабу, күмер тузаны эчү турында ул, билгеле, беркайчан хыялланмады.* Н.Фәттах. *Мәсьәләне туп-туры әйтеп салган. Шулай, шулай, дигән, синең күршедәге яшь егет Миңнефәтихка чыгасың килеп йөргәненне, аның белән бергә Кемерово якларына шахтага китәргә план корганыгызны да беләм.* М.Мәһдиев

2) Җир асты байлыкларын казу урыны, җир асты корылмасы. *Безнең белән клетька утырып, шахтага төшәргә әзерләнгән шахтёрлар килеп тукtadы.* Һ.Такташ. *Иң элек мин шахтаның нәрсә һәм шахтёрның кем икәнен белдем. Җир өстендә эшләсәм дә, берничә тапкыр --- кулга шахтёр лампасы тотып, шахтага да төштем, егетләрем эшләгән забойларда да булдым.* Ә.Еники

**ШАХТЁР** *и. рус* Шахта эшчесе. *Күңелен айкаган хисләр өермәсенә түзә алмыйча, Мөнирҗан җырлап җибәрде: Шахтёр егет күмер чаба, Вак-вак итеп кисәген.* Н.Әхмәдиев. *Брезенттан тегелгән калын, авыр кием, аягына резин чуни, башына шахтёр каскасы киеп алгач, Нияз гомере буе шахтада эшләгән кешегә охшады да куйды.* Д.Каюмова

**ША́ХЫР-МАХЫР** *и. нем. гади с.* **1.** Үзенә табыш каеру өчен төрле хәйләгә, алдауга корылган килешү яки эш. *Урманчыны бик нык тараганнар иде, печән чаптырып шахыр-махыр килгәне өчен, аңа нык кына эләккән иде.* М.Мәһдиев. *Тегеләр, лапаска яшеренеп кенә, нindidер шахыр-махыр ясап маташа.* Р.Фәизов

**2.** *рәв. мәгъ.* Аннан-моннан, өстән-өстән, эштер-өштер генә. *Шахыр-махыр гына эшләү*

◊ **Шахыр-махыр китерү** Хәйләле эш алып бару, алдау-йолдау юлы белән табыш алу. **Шахыр-махыр кору** *к.* **шахыр-махыр китерү**. *[Шәрипов] итәк астыннан шахыр-махыр корып ята бугай.* Р.Ишморат

**ШАҺ** I *и. фар.* 1) Кайбер Көнчыгыш илләрендә монарх титулы һәм шул титулга ия булган кеше. *Касыймовка патшаның ике ил арасында*

*сәүдә мөнәсәбәтләре урнаштырырга тәкъдим ясалган грамотасын Һиндстан шаһына тапшыру йөкләнә.* М.Мәһдиев. *Мисыр шаһы мәлик Рәйянның төше сурәтләнелә, тик юрый белүчеләр бу төшенә җавап таба алмыйча гаҗизләнәләр.* Ф.Яхин

2) *күч.* Билгеле бер урында, җәмгыятьтә, мохиттә төп көч һәм хөкемдар булып торучы шәхес. *Шул чагында күтүченең бүлмәсенә җен шаһының иркә кызы килеп кергән.* К.Тинчурин. *Бу кызлар шаһы әйтте: – Мән, бу шәехне икрам итеп озаткач, --- егетемне төшемдә күрдем.* Ф.Халиди

3) *күч.* Хуҗа, баш, башлык. *Ала каз башын текә күтәргән, ди, әйләнәтирәсенә гаҗәп җитди чырай белән масаеп карана, ди, әйтерсең дөньяның шаһы булган, шундый горурлык, ди, үзендә.* Ә.Еники

4) *күч.* Кем яки нәрсәләр арасында иң югары торучы, шуларның иң күренекле, иң дәрәҗәле вәкиле. *Һич килештермим синең төсле гүзәллек шаһына, Ичмасам, бер хисле шагыйрь дә килеп кол булмаса.* Г.Тукай. *Мең яшә, гөлләр шаһының иркә, назлы былбылы, Бел: матурлыкта синең юк тиңдәшең, син – җир хуры.* Ф.Бурнаш. *«Дөньяның бөюче шаһы» буларак барлык кыйтгаларда танылган мәшһүр милләттәшебез Рудольф Нуриевның якты истәлегенә багышланган классик балет буенча --- уздырылган халыкара фестиваль дә гаҗәеп якты бер бәйрәм буларак истә калды.* Шәһри Казан

**ШАҺ** II *и. фар.* Шахмат уенында каршы уйнаучының короленә нинди дә булса фигура белән ясалган турыдантуры һөҗүм

**ШАҺӘСӘР** *и. фар.* Шедевр, үрнәк сәнгать әсәре. *Яшь буынга килгәндә, күптән түгел генә поэзия китаплары чыгарып, шаһлар гына аңларлык (элитар), шаһәсәрләр (шедеврлар) иҗат итә торган Җәүдәт Сөләйман исемле шагыйребез танала башлады.* Р.Батулла. *Тикмәгә генә түгелдер, «Шаһнамә» шаһлар өчен язылган шаһәсәр, ягъни шедевр диеп атала.* Казан утлары

**ШАҺБАЗ** *и. фар. иск.* 1) *к.* **лачын**. *Шаһбазлар Каф тавына күчеп киткән, Урыныңа – козгын, байгыш кунып калган.* М.Акмулла

2) *күч.* Батыр, куркусыз кеше. *Ирәннәргә торыр ир шаһбазы Аудан кайта дала буйлатып.* С.Әхмәтҗанова

**ШАҺЗАДӘ** *и. фар.* 1) Шаһ улы

2) Тәхет варисы. *Бервакытта Чин шаһзадәсе үзенең йөз меңлек гаскәрен алып килеп, сарайга һөҗүм итеп тә караган иде.* Г.Рәхим. *Мәмләкәт тәхетенә тәнендә хан каны булган солтан яки шаһзадәләр генә дәгъва кыла ала.* В.Имамов

**ШАҺИН** *и. фар. иск.* Лачын кошлар семьялыгыннан сапсанга охшаган ерткыч кош; җирән башлы лачын; *русча-сы:* **рыжеголовый сапсан**

**ШАҺИНӘ** *и. гар.* Шаһ хатыны яки хатын-кыз шаһ. – *Беләбез, беләбез, бер кызыңны саами егетләре Кола ярыматавының королевасы итәргә теләгәннәр. Ә без Фаягөлне Кола ярыматавының шаһинәсе, патшабикәсе итәбез, – диде Шәүкәт ---.* А.Хәсәнов. *Шаһинәләр төсле гүзәл дә син, Ханбикәләр кебек кырыс та...* М.Шиһапов

**ШАҺИНШАҺ** *и. фар. иск.* Шаһлар шаһы, бөек шаһ; патшаларның патшасы, император. *Ярым сәгать микъдары сөйләшмичә һәм тын гына алларына карап, түбәнчелек белән шаһиншаһ шаһзадә Асылның күренүен көтеп тордылар.* К.Насыйри. *Төркиләр Тимер капканы алгач, фарсылар шаһиншаһы тәмам курка кала.* М.Хәбибуллин

**ШАҺИТ** *и. гар.* 1) Берәр эш-хәл, күренеш яки вакыйганы күрүче, читтән карап торучы, белүче кеше. --- *гитлерчылар, үзләренең җинаятьчел эзләрен яшерер, шаһитларны калдырмас өчен, барлык тоткыннарны кырып бетерергә маташачаклар.* Г.Әпсәләмов. *Нурихан җансыз багана кебек сураеп торды. Соңлап ишетелгән гайбәт кычыткannan да хәтәррәк чага икән. Шаһитларның барысы да гүр иясе. Кемнән сорыйсы хәзер...* Н.Гыйматдинова

2) *юр.* Җинаять эше кузгатылган вакыйганы күреп белгән, андагы вакыйгаларның барышын сөйләп бирә алырлык кеше; танык, гуаһ. *Шаһитлардан сорау алу да әллә ни кызык булмады.* Л.Ихсанова. *Менә икенче көн инде залда суд бара. Судьялар, прокурор һәм адвокатлар хөкемдә булучыларга, шаһитларга сораулар бирәләр.* Р.Фәизов

3) *этн.* Никах вакытында кыз һәм егет ягыннан аларның бу никахка ризалык сүзен таныклаучы кеше. *Ул, никах вакытында кызның ризалыгы турында шаһитлардан сорау алучы мулла шикелле, җавапта төгәллек таләп итте.* М.Әмир. *Инде менә барысын да аңлатып биргәннән соң: – Алайса, шаһитларны – кияү ягыннан Нурисламны, Маһирә ягыннан Зәкияне әзерлик. Никахны аш өендә үткәрербез.* Г.Галиева

4) Юридик мәгънәгә ия булган берәр фактны раслый яки шәхеснең нәрсәгә дә булса хокукын күрсәтә торган рәсми документны язганда, укыганда булган кеше. *Өйләнешүчеләр загста язылышканда, аларны белә торган ике кеше шаһит булырга тиеш икән.* В.Нуруллин. *Васыятьнамә шаһитлар каршында ачып укылды.* Безнең гәҗит

5) Берәр эш-хәл, күренеш яки вакыйганы раслый торган әйбер, дәлил; шул эш-хәл, күренеш яки вакыйганы раслардай нигез. *Тик култык астыннан агып чыккан кан гына аның үлек икәнлеген расларлык шаһит иде.* К.Тинчурин. *Керпе дә баласына йомшагым дип әйтер, ди шул. Менә шуның тере шаһиты булырга туры килде безгә. Шул шыр ялангач, үзләре килбәтсез балаларын ана керпенең ялап-ялап --- иркәләгәнен күрсәгез икән!* А.Хәсәнов

6) *күч.* Нинди дә булса вакыйгага (пассив) катнашкан, шунда булган нәрсә. *Шулай әйтеп, Мәрьямбикә улының учына кулдан кулга йөреп, мең хәсрәткә шаһит булып, изелеп, таушалып беткән өчлек белән берлекне китереп салды.* А.Гыйләҗев. *Таңнар шаһит иде, Таулар шаһит иде, Җилләр шаһит иде, Гөлләр шаһит иде Безнең мәхәббәткә, кадерлем.* Ф.Яруллин

**ШАҺИТЛЫК** *и.* 1) Нинди дә булса эш-хәл, күренеш яки вакыйга шаһитының сүзләре, күрсәтмәсе; таныклык, гуаһлык. *Әгәр укучылар бу язманы озак яшәп киткән бер кешенең үз заманы турында калдырган чын шаһитлык сүзе дип кабул итсәләр, без фәкыйрегез дә шуңа бик канәгать булачакбыз.* Ә.Еники

2) Шаһит вазифасы. *Заманча биеп, арып, бераз тынычлангач, Рөстәм, хәләл җефетеннән рөхсәт алып, туйда шаһитлык вазифаларын башкарган Надияне танцыга чакырды.* Т.Галиуллин

3) *юр.* Җинаять эше кузгатылган вакыйга шаһитының рәсми күрсәтмәләре, сүзе; шундый күрсәтмә бирүче кешенең статусы. *Аталары мәрхүм судтан судка ялган шаһитлыкка йөреп гомерен уздырган булса, болары да шул табак ялап көн итәргә тырышалар.* Т.Гыйззәт. *Җаббаров, чын күңелдән борчылып, картка киңәш бирергә уйлады: – Судка гариза яз, энәсеннән җебенә хәтле теркә. Мин шаһитлыкка риза!* Н.Гыйматдинова

**ШАҺИТЛЫ́К ИТҮ** *ф.* 1) Судта шаһит булу, үзеңне җинаятьтә шаһит дип

тану, җинаятьнең булуын раслау. *Соңра бу ике дус, «урлап йөри» дип, Мохтар өстеннән полициягә жалоба бирделәр вә, ялган шаһитлык итеп, аны полиция участогына яптырдылар.* М.Акъегет. *Аннан соң залга бер-бер артлы тагын берничә шаһит чакырылды. Аларның барысы да диярлек Вәсиләгә каршы шаһитлык итте.* Ә.Сафиуллин

2) Гомумән, нәрсәне дә булса юридик раслау

**ШАҺИТЛЫ́К КЫЛУ** *ф. к.* **шаһитлык итү**. *Гаепсез көйгә үзләрен гаепләгән кәгазьгә кул куйганнары, башкаларны гаепләп шаһитлык кылганнары өчен гөнаһлымы соң бу тотаклар?* Ф.Сафин. *Суд каршында шаһитлык кылганың, милициягә гариза язганың юкмы?* И.Сираҗи

**ШАҺЛЫК** *и.* 1) Шаһ дәрәҗәсе. *Әфганнарга каршы сугышта фарсы шаһы җиңелә һәм, тәхетеннән ваз кичеп, үз кулы белән шаһлык таҗын әфганнар башлыгы Мәхмүд башына кидерергә мәҗбүр була.* М.Гайнетдинов. *Миннән бигрәк шаһлык сиңа лаек, углан.* Ю.Сафиуллин

2) Башында шаһ торган дәүләт. *Ул татарлар мөселман булып, Караханилар дәүләтенең һәм Харәзем шаһлыгының төп халкын тәшкил иткәннәр.* М.Әхмәтҗанов

3) *күч.* Баш, өстен булу хәле. *Аны йөртте зур дәрт, ирек дәрте, Гаделлекнең туар шаһлыгы.* Н.Исәнбәт. *Мәхәббәтнең офыгы чикләрсез! Кешеләр юк җирдә хисләрсез. Хисләр ташып тора һәр халәт. Җирдә шаһлык итә мәхәббәт!* М.Ногман

◊ **Шаһлык сөрү** 1) Шаһ булып тору; 2) Ил белән идарә итү. *Асты өскә килде дөнья. Кол сыйныф алды ирек: Инде ул шаһлык сөрә, Иркен сулап, күкрәк киереп.* Г.Харис; 3) Өстенлек итү, хөкем сөрү, хуҗа булу. *Ул сарайда мәңге шатлык һәм ирек шаһлык сөрә, Ул сарайда хөр йөрәк, көчле, батыр ирләр тора.* Һ.Такташ

**ША́ШКА** *и. фар.* 1) Шахмат тактасы кебек тактадан, уникешәр ак һәм кара төстәге яссы түгәрәк шакмаклардан (төймәләрдән) торган өстәл уены җыелмасы. *Зиннәтнең уку йортына төрле кирәк-ярак аласы бар иде бит. Доминодыр, шашкадыр, фәләндер.* Г.Бәширов. *Шулай әрепләшү-даулашу киткәч, инспектор партнёрына: – Торып торсын, соңыннан... – дип, шашка тактасын читкәрәк шудырып, протокол төзергә тотынды.* З.Фәйзи // Әлеге төймә үзе. *– Сиңа карасымы, агымы? – дип, ике кулына ике шашка йомарлап, Җамалидан аның берсен алдыртты.* М.Гали. *Йолдызлы бүрек тә юк, бил каешы да юк, шашка төймәләре кайсы кайда сибелеп яталар, кыскасы, өй эче нәкъ элеккечә бушап, ятимләнеп калган иде.* Балачак энциклопедиясе

2) Шул тактада шакмакларны билгеле кагыйдәләр нигезендә күчереп, каршы якны кысрыклап уйный торган өстәл уены. *Зал уртасында күпчелек кызлар иде, егетләр исә көлешеп, шаярышып читтә, стена буенда утыралар, шашка, домино уйныйлар иде.* Н.Фәттах. *1950 елда ул, РСФСР беренчелегенә шашка турнирында, унҗиде мөмкинлектән унбер ярым очко җыеп, мастер исемен яулый һәм икенче урынга чыга.* М.Хуҗин

3) Күп кенә илләрдә такса белән кеше йөртә яки йөк ташый торган транспортны билгеләү символикасы. *Таксист янында гына иде, егерме минуттан читта түбәсенә сарылы-каралы шашка беркетелгән ак «унлы» күренде.* Ф.Бәллүр

4) *махс.* Шартлату, төтен булдыру һ.б.ш. максатларда кулланыла торган, прессланып тартмачыкка тутырылган пироксилин яки башка шартлаткыч матдә. *Кинәт Геращенко, ашыгып, противогаз сумкасын актара башлады. – Шашка исен... беләм мин, ул... ул мондый булмый. Аның исе бүтән, – дип кабатлады ул, тотлыга-тотлыга.* Ф.Латыйфи

**ША́ШКАЧЫ** *и.* Шашка уены спортчысы; гомумән шашка уйнаучы. *Казан шашкачылары (һәм Татарстан шашкачылары) арасында беренче булып Рәшит Нәҗметдинов беренче категория ала.* М.Хуҗин. *Командалар ярышында беренчелеккә Яшел Үзән шашкачылары чыкты.* Татарстан яшьләре

**ШАШКЫН** *с.* 1) Ярсулы, ярсып, ашкынып торган, ташкын хисле. *Асаф кичәге шашкын хисләрнең тагын уянуыннан куркып, чынлыкта исә шуларның кабатлануын теләп, Сылуның сумкасын кулына алды.* М.Мәһдиев. *Тик Алмабикәнең шашкын йөрәгендә китап сүзләре өчен аз гына да урын юк иде.* С.Поварисов

2) Ярсу хисле, җилкенчәк холыклы. *Көз дә җитте, кыш та үтте, Хәтимәкәй, ашкынма, Гамьсез шашкын яшьлегең дә Күмеләдер ташкынга.* И.Юзеев. *Хәтта Шаһимәрдан да элеккеге гаярь, гамәлдә алдын-артын уйлап тормыйча эш итүче шашкын адәм түгел инде.* Ф.Яхин

3) Шашкан, шашынган. *Валия озак тормады. Беркемне күрмәс дәрәҗәдә шашкын кыяфәттә чыгып, арбага утырды.* Р.Батулла. *Ишектән чыккан-да, бер-бер хәл кылуы мөмкин шашкын күзле тиленең.* Т.Галиуллин

4) Көчле, дәһшәтле, котырынган (табигать күренешләре тур.). *Югарыда шашкын җил иде, ахрысы, кырык-карта төсле катлы-катлы болытлар, биек шарламадан атылып төшкән судай, актарылып-актарылып кайнадылар.* А.Гыйләҗев. *Киң офыкларга җәелгән күксел урманнарны, талгын җилләрне, шашкын диңгезләрне калдырам.* Г.Сабитов

**ШАШКЫНЛЫК** *и.* Ярсулык, тынгысызлык; шашыну хисе. *Кинәт Саҗидә күзләрен ачты. Аның күз карашы, әүвәлге шашкынлыгын югалтып, ничектер нурланып, ачыкланып киткән кебек иде.* М.Галәү. *Шау-шу, кычкырыш, шашкынлык бөтен өйне, йортны басты.* Г.Ибраһимов

**ШАШЛЫК** *и. төрки* Тимерчыбыкка (шешкә) яки шампурга кидереп, төрле тәмләткечләр өстәп күмер өстендә кыздырылган ит кисәкләреннән гыйбарәт ашамлык; кәбапның бер төре. *Урман яланнарына, түгәрәк күл буйларына пикникка, шашлыкка чыккан чакларын сагынып исенә төшерә ул. Шашлыкның иң тәмле калҗалары белән хуҗасы иң башта аны сыйлый иде.* А.Хәсәнов

**ШАШЛЫКХАНӘ** *и.* Шашлык әзерләү, сату һәм ашау урыны. *Җәяүлеләр урамында җәен ачык һавада урнашкан «Шашлыкханә плюс сыра» исемле кафе янышнан --- узып барганда, Фәтхулла хәзрәт каршына популяр фельетончы Гатаулла Зәхмәти йөгереп килеп танышты.* А.Тимергалин. *Дөрес, законда стационар булмаса да, җәмәгать туклануы предприятиесе дигән статуска ия сәүдә нокталарына, әйтик, шашлыкханәләргә искәрмә ясалган.* Әлмәт таңнары

**ШАШЛЫКЧЫ** *и.* Шашлык ясаучы һәм сатучы. *Карап торырга бик елгыр адәмгә охшаган шашлыкчы Шубариннан төргәкне алгач, уң кулын йөрәк турына куеп әйтте: – Утырыгыз, ял итә торыгыз, хәзер чәй китерерләр, шашлык унбиш минуттан әзер булыр.* Р.Мирхәйдәров. *Шашлыкчылар --- учак тергезделәр, урман һавасына әчкелтем төтен, кыздырган ит исе*

*кушылып, җил белән тирә-юньгә таралды.* Д.Булатова

**ШАШТЫРДАТУ** *ф.* Коры, юка нәрсәләрне кузгатып, шаштыр-шоштыр иткән тавыш чыгару, шыштырдату. *Җәүдәт, аяк астындагы үләннәрне шаштырдатып, безнең янга килеп туктады.* Г.Ахунов. *Шул уе белән канатланып, кытыршы яфраклы карамаларны шаштырдатып ике якка аера-аера, ул тип-тигез офыккача сузылган хәтфәдәй яшел уҗым кырына килеп чыкты.* А.Вергазов

**Шаштырдатып алу** Тиз, кыска гына вакыт эчендә шаштырдату

**Шаштырдатып кую** Азга гына бер тапкыр шаштырдату. *Бозау аяк астындагы саламны шаштырдатып куйды*

**Шаштырдатып тору** Даими, бертуктаусыз шаштырдау; әле, хәзерге вакытта шаштырдату. *Кызчык кесәдәге акчаларын шаштырдатып тора*

**ШАШТЫРДА́У** *ф.* Кипкән яфрак, үлән, кәгазь кебек нәрсәләргә кагылганда, уганда кыштырдаган тавыш барлыкка килү, шаштыр-шоштыр иткән тавыш чыгу, шыштырдау. *Канау аръягындагы биек үлән дуамал җилгә шаштырдап чайкала, егыла, тора, бөтерелә иде.* М.Мәһдиев. *Яфраклар шаштырдаган тавышка Җамали кинәт сикереп торды.* А.Вергазов

◊ **Шаштырдап торган** Өр-яңа, тип-тигез, шоп-шома, таушалмаган, кыштырдап торган (акча, кәгазь һ.б.). *Шаштырдап торган акчалар күңелне кытыклый*

**Шаштырдап алу** Тиз, кыска гына вакыт эчендә шаштырдау

**Шаштырдап кую** Аз гына, бер тапкыр шаштырдау. *Кинәт җил исте, кипкән үлән сабаклары шаштырдап куйды*

**Шаштырдап тору** Даими, бертуктаусыз шаштырдау; әле, хәзерге вакытта шаштырдау. *Артурның кулындагы яфрак букеты шаштырдап тора*

**Шаштырдый башлау** Шаштырдарга тотыну

**ШАШТЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **шашу**. *--- үз килененнән моны ишетү инде аны бөтенләй шаштырды, агулы хәнҗәр чәнчелгән кебек, йөрәген тотты да: – Уффф... оятсыз, кәнтәй, – дип, янындагы уклауны алып киленгә бәрде.* Г.Ибраһимов. *Бу хәбәр Хантимерне шаштырган иде.* Н.Гыйматдинова

2) Көчле тәэсир итү, көчле хисләр уяту. *Ләкин бүген минем арыган, алҗыган йөрәгемә мәхәббәт җылысы да, үткәннәргә алып киткән сагыш та, ашкындыра, шаштыра торган ярсу көч тә кирәкми.* Л.Ихсанова. *Син минем йокымсыраргa мәҗбүр ителгән хисләремне уяттың. --- Синең гүзәллегең шаштырды, кызып китеп, ипсез кыланганмын икән, кичер.* А.Гыйләҗев

**Шаштыра бару** Торган саен тагын да ныграк шаштыру

**Шаштыра калу** Кинәт шаштыру; берәр сәбәптән шаштыру. *Ул арада күктән бер зилзилә төшеп, халыкларны шаштыра калды.* Ф.Яхин

**Шаштыра төшү** Тагын да ныграк шаштыру; бераз гына шаштыру. *Аның болай сүзсез калуы мине тагын да шаштыра төште.* Ш.Маннур

**Шаштыра язу** Аз гына шаштырмый калу. *Бу көтелмәгән вакыйга агитаторны да, халыкны да шаштыра язды.* Һ.Такташ. *Инде Гайзулла, кулына күтәреп куе таллыкка алып кергәч, Таҗылбанатның кайнар сулышы аны тәмам акылдан шаштыра язды.* М.Хәбибуллин

**Шаштырып бетерү** Тәмам шаштыру. *Җәүдәтнең башын бутап, шаштырып бетергәнсең. Кара аны, кызый, мин андый эшләргә юл куймам.* Г.Каюмов

**Шаштырып җибәрү** Кинәт шаштыру. *Бер кешенең бу кадәр нык каршы торуы финнарны тәмам шаштырып җибәрә.* Г.Әпсәләмов. *Тышта күзгә бәрелгән картина башта шаштырып җибәрде.* Ш.Усманов

**Шаштырып тору** Даими, бертуктаусыз шаштыру; әле, хәзерге вакытта шаштыру. *Күрәзәләре, сихерчеләре, кәрамәтләре, йолдызга һәм башка нәрсәләргә карап һәртөрле серләрне сөйләүчеләре күп булып, һәр төрле юллар илә надан халыкны шаштырып торалар.* Шура

**ШАШТЫ́Р-ШОШТЫР** *иярт.* Корыган яфрак, кипкән үлән сабаклары бер-берсенә тиюдән, берәр юка, җиңел нәрсәнең икенчесенә җиңелчә орынуыннан, ышкылуыннан, нинди дә булса хәрәкәттән барлыкка килгән өзек-өзек тавышны белдерә; чаштыр-чоштыр. *Атлаган саен, аяк астында көзге яфраклар шаштыр-шоштыр килә*

**ШАШУ** *ф.* 1) Нормаль фикерләү сәләтен югалту, юләрләнү, акылдан язу, психик авыруга әйләнү, тилмерү. *Җанлы кара шәүлә булып, акылыннан шашкан хатын ындыр табагына килеп җиткәндә, төн авышкан иде инде.* Н.Фәттах

2) Аптырау, коелып төшү, нишләргә белмәү. *Җамали куркудан шашкан бичара Сафураның бу мәшәкатьләренә күз салмады.* Г.Ибраһимов

3) Хисләр ташу, эчке кичерешләрдән тыела алмас дәрәҗәгә җитү, нормаль хәлдән чыгу, чиктән ашу. *Мондый минутларда аларның һәр икесенең йөзләрендә нур балкый, йөрәкләре шатлыктан шашардай булып тибә иде.* Ф.Яруллин

4) Артык котырыну, нишләгәнен белмәү дәрәҗәсендә ярсу, дулау, кычкыру. *Хәмбәл юлда атна буе котырынды, шашты.* В.Имамов. *Озакламый --- басып керүчеләр болай да чамалы гына булган җиһазларны җимерергә тотына ---. Нәтиҗәдә өстенлек алган як шаша, нишләгәнен дә белми.* К.Җәмит // Башкаларга мөнәсәбәт мәсьәләсендә киртәдән чыгу, үзенә артык ирек бирү, инсафлылыкны, тәртипне оныту. *Наркоманнар, фахишәләр, Караклар өере шаша. Киллер үтерә ялланып... Илне саилче баса!* С.Гәрәева. *Кешеләр аптырап калды. Ник шаша бу угланнар, нигә бәйдән ычкынган эт шикелле котырыналар?* М.Әмирханов

5) *күч.* Кем яки нәрсә белән дә булса артык, чамадан тыш мавыгу, саташу; чын күңелдән берәр эшкә бирелү. *Җан азыгы булырдай эш табылса, ул яна, шаша, көя!* А.Гыйләҗев. *Без Гамил белән, ир-хатыннан битәр, иҗатка багынып, сәхнә, роль дип шашкан ике сантый артист идек.* Н.Гыйматдинова

6) *күч.* Котырынып, дәһшәтләнеп дулау (табигать күренешләре тур.). *Кайный, ярсый, бәргәләнә, Үкерә, шаша елга.* Ф.Яруллин. *Күрәсеңме әнә диңгезне?! Дулый, шаша, ярларына сыймый, Тынгы тапмый, ул нәрсәдер эзли...* М.Кәбиров. *Кайдан үзенә дөньяның бар каһәрен, бар үчен җыйган – котыра. Шаша җил, кешене камчылый.* Р.Камал

**Шаша бару** Торган саен ныграк шашу. *Ул бакчаны ясау эше җиңел түгел. Шул турыда уйлый-уйлый шаша барам ---.* К.Тинчурин. *Туктатмакчы булам тегеләрне. Кая ул! Әйткән саен, ныграк шаша баралар.* Н.Әхмәдиев

**Шаша башлау** Шашырга тотыну. *Соңгы вакытта күргән-кичергәннәре шул тиклем буталчык һәм җан өзгеч булып, әллә акылыннан шаша башладымы ул?* М.Кәбиров. *Син нәрсә мыгырдап утырасың? Кильки ашап, акылдан шаша башладың мәллә?* Г.Каюмов

**Шаша калу** Берәр сәбәптән, гамәлдән, эштән соң шашкан хәлгә килү. *Сәхип күзләренә ышанмады: «Я Ходай,*

*бу Урманов түгелме соң?» – дип шаша калды...* Г.Ибраһимов. *Халык шаша калды, бәхетләре колачланды, күңелләре канатланды.* Ф.Яхин

**Шаша язу** Чак кына шашмый калу. *Ярый әле Булат исән икән, үтергәннәрдер дип уйлый-уйлый, акылдан шаша яздым.* К.Тинчурин. *Хәлим тәмам шаша язды. Тәкыя карчык күзләрен карамаса, шашар иде дә, мөгаен.* Г.Гыйльманов

**Шашып алу** Беркадәр, бераз ара шашу. *Әмма сәҗдә җиле дә, сабах җиле дә вакыт-вакыт шашып алалар.* С.Поварисов. *«Шахтёр абыең тальян тарта-тарта Җырлый», – диләр шулай кайвакыт, Моңга тулып җаны шашып ала, Төзекләнеп китә һәр ватык.* Ф.Яхин

**Шашып бетү** Тәмам шашу. *Ул бу эшкә нигә тыгылганына да үкенде. Ике көннән соң ни булырын уйлап та шашып бетте.* Г.Ибраһимов. *Әгәр дә уйлана калсаң, Шашып бетәргә була. Илдән түгел, Җир шарыннан Качып китәргә була.* Н.Сафина

**Шашып йөрү** Озак вакытлар, сөйләү моментында шашкан хәлдә булу. *Дамирдан хат килгән көннәрне Җәүһәр мәхәббәт шәрабын коштабаклап эчкәндәй тилереп, шашып йөри иде.* Ф.Яруллин. *Пионерга керде, комсомол булды, спорт белән җенләнде, музыкаҗыр белән шашып йөрде...* Р.Вәлиев

**Шашып китү** Нindидер сәбәптән, кинәт шашу. *Шул кычкыруга бөтен зиндан шашып китә, тоткыннар яткан җирләреннән сикерешеп торалар да һәммәсе камераларының тимер тишекләренә ташланалар.* Г.Ибраһимов. *Арада иң сабыры Гыйзелниса карчык чыдамаган, болай дигән: – Үтә шашып киттең, Мәрхәбә. Оятыңа көч килер.* М.Кәрим

**Шашып кую** Уйламаганда, кинәт шашу. *Шулай үзеңне үзең дәваламасаң, айлар буе бәйдә утырып, көтмәгәндә генә акылдан шашып куюың да бар.* А.Хәсәнов. *Төптән күтәрелгән асыл моңнан Шашып куя йөрәк... Патефон да килгән... завклуб та Асыл егет, димәк.* Н.Сафина

**Шашып тору** Аптырап тору, нишләргә белмичә тору. *--- ялгыз калган Гәрәй кинәт сәкегә утырды. Кулын йөзенә, маңгаена куеп бераз гына уйланып, шашып торды да акырып җибәрде.* Г.Ибраһимов. *Уйланырга куркып басып торам, Шашып торам, искә килалмый.* Р.Миңнуллин

**ШАШЫНДЫРГЫЧ** *с.* Шашындыра торган, шашыну дәрәҗәсенә җиткергән. *Хәлил кайтканнан бирле тирәягындагы йогышсыз исләрдән җәфалана, юл, шпал, вагоннарга сеңгән Рәчәй исләре аны җәһәннәми шашындыргыч мохиткә сөйрәп алып кереп китәләр иде.* А.Гыйләҗев

**ШАШЫНДЫРУ** *ф.* 1) Кешенең рухи халәтенә бик көчле тәэсир ясау, шашыну дәрәҗәсенә җиткерү. *Кызның юка ефәк күлмәге астында тәмам җитлеккән алма кебек тыгыз күкрәкләрен учында тою Сәетне тәмам шашындырды...* М.Хәсәнов. *Асылгәрәй картны кайтаралар дип торганда, Маһинур абыстайны алырга килүләре барысын да шашындырды, куркытты.* Ф.Бәйрәмова

2) Гаҗәпләндерү, сокландыру, искиткеч нәрсә белән шаккатыру. *Көзге урман матурлыгы белән шашындырды*

**Шашындыра бару** Торган саен тагын да ныграк шашындыру

**Шашындыра башлау** Шашындырырга тотыну. *Ләкин аның миңа сер бирмәве берзаманны тәмам шашындыра башлады.* Кызыл таң

**Шашындыра язу** Шашындыру дәрәҗәсенә җитү. *Яңадан төпкә киттем. Авызга су тулды. Дөнья белән саубуллашыр вакытым җитте, диген уй акылымны шашындыра язды.* Л.Бадыйкшан

**Шашындырып җибәрү** Шашындыруга этәргеч бирү, кинәт шашындыру. *Кызның --- шелтә белән дә сөйләшүе, ерактагы җырга колак салып та, янындагы Сәлимне, ичмасам, барга да санамавы егетне тәмам шашындырып җибәрде.* Г.Әпсәләмов. *Канлы вакыйга бөтен илне тетрәтә. Бу кан контрреволюцияне янә шашындырып җибәрә.* С.Поварисов

**ШАШЫНУ** *ф.* 1) *к.* **шашу**. *Әнә «алга киткән милләтләр» бүген югары технологияләр белән шашына бит.* Б.Рәхимова. *Дулкынлана диңгез, күбекләнеп Котырына, ярсый, шашына.* Ф.Зыятдинова. *Сасулин аның кулындагы балтасына килеп ябышты. – Нишләвең, Володя?! Шашындыңмы әллә? Акылыңа кил! – диде ул.* Ә.Сафиуллин

2) *куч.* Кемгә дә булса гашыйк булу; хисләр ташу. *Гыймран, ач күз, өйләнеп кенә кызган ташын бастырса икән. Аңа Фәһимә дә, Нурсөя дә кирәкми, ул Халидә дип шашына иде.* Н.Гыйматдинова. *Яшь хатынның аз гына кагылуга ук көйдереп ала торган тыгыз күкрәкләрен тоемлаудан, әледән-әле кайнар кочакларын татудан Миңнехан тәмам миңгерәде, исерде, шашынды...* В.Имамов

**Шашына бару** Торган саен тагын да ныграк шашыну. *Әмма Мөдәррис аның саен катырак сүгенә һәм шашына барды.* Ф.Яхин. *Ялкынга сибелгән су төкерек кебек чыжлап юкка чыга. Ут шашынганнан-шашына бара.* Д.Каюмова

**Шашына башлау** Шашынырга тотыну. *Андый чакта ул ни эшләгәнен белмичә дуамаллана, шашына башлый.* А.Вергазов. *Колшәрифнең бу тәкъдимен ишеткәч, халык тәмам шашына башлады. Ике яктан да бүрекләр очты.* Р.Батулла

**Шашына төшү** Бераз шашыну; тагын да ныграк шашыну. *Үзе җавабын көтеп тормады, нәрсәгәдер шашына төшкән күзләрен малайлар тары чәчеп йөргән якка төбәп дәвам итте.* З.Зәйнуллин

**Шашына язу** Шашыну дәрәҗәсенә җитү. *Ахыр чиктә Сталинның сабырлыгы төкәнде, Троцкийның шашына язардай очынуы күңел кайтаргыч дәрәҗәгә җитте, ул моңа чик куярга тиеш иде.* Ф.Сафин. *– Миңа, хатын, сиңа каба төбе ясадым, – дип шаяртты һәм каба төбен Бибиәсмага сузды. Ярык каба төбен күреп, ул шашына язды: – Һәй, чукрак! Мыскыл итеп торган буласың!* Д.Каюмова

**Шашынып йөрү** Хәзерге моментта яки күпмедер вакыт дәвамында шашыну. *Егет-җилән, кыз-кулән бар да шашынып йөри.* Г.Әпсәләмов

**Шашынып китү** Кинәт, тиз арада шашынган хәлгә килү. *Икенче җәйне, урак өсте алдыннан Мирвәли аерата тилереп, шашынып китте.* А.Гыйләҗев. *Ханым шашынып китте һәм өстендәге кофтасын салып ук ташлады.* Ф.Яхин

**Шашынып кую** Кинәт яки вакыт-вакыт шашыну. *[Рәхилә:] Күңелем төшенке. Үз-үземне сөймим. Белмим, нигә. Йөрәк шашынып куя... Әллә ниләр эшлисе килә.* А.Гыйләҗев

**ШАШЫП** *рәв.* Бик көчле, ярсып; онытылыр дәрәҗәгә җитеп, белештермәс дәрәҗәдә, чын күңелдән. *Хатын --- ирнең муеныннан, колак тирәләреннән шашып үбә башлады.* Р.Сәгъди. *Дөм сукыр син, Рәфис! Шашып яратам бит мин сине!* А.Вергазов. *Ишетәсезме, кошлар шашып сайрый, Сөенешеп язлар килүенә.* Ә.Ситдыйкова

**ШАЯН** *с.* **1.** 1) Мәзәк, көлке, көлкеле; шаяртулы, шук. *Күңеленә көн нуры төшкән кеше генә шаян сүзне кабул итә, үзеннән дә, бүтәннән дә рәхәтләнеп көлә белә.* М.Галиев // Шаяру,

шуклык белән тулы. *Искә төшеп куя егет чаклар, Шаулап узган шаян гомерләр.* Ш.Маннур. *Сания, бернәрсә дә сизенмәгән булып, шаян тавыш белән: – Нәрсә борыннарыгызны салындырдыгыз? – дип шаярып алды да Борисов турында сөйләргә керешә.* С.Сабиров

2) Мәзәкчән, җор; шук, наян, уенчак. *Һәр көнне диярлек кичкырын безнең күрше Клавдия Петровна Шарик кушаматлы этен ишегалдына уйнатырга алып чыга. Гадәттә, балалар аларны көтеп алалар, чөнки ул шаян этне бик яраталар.* Ү.Саттаров. *Уларын һаман яхшылыкка өйрәтеп торган, эшчән алма апамны шук, шаян кыз итеп күз алдына китерү миңа шактый читен иде.* Г.Вәлиева

3) Тапкыр, чая. *Ул дәрт, ул янып торган уйнак күзләр, ул шаян тел, ул талдай нечкә бил... Хәзер инде аларның һәммәсен картлык күләгәсе каплый башлады.* С.Поварисов. *Фәнис уттай холыклы, шаян телле.* Р.Хәсәнова

4) Борчып, тынычсызлап торган; тынгысыз, тынычлык белми торган. *Каяндыр килеп чыккан шаян җил су өстендә тирбәлгән иртәнге сыек томанны ерткалап тарата барган саен, күз алдындагы күренеш тә үзгәрә, төсләре ачыклана ---.* Ф.Латыйфи. *Маңгай тирәсендәге чәчләре кызның күзенә төшеп борчый, башын артка селкегәч, шаян чәчләр артка китә дә берникадәр вакыттан тагын, тыңлаусызланып, алга тәгәриләр.* Тамаша // Төрле хәлгә куя, төрле кичерешләргә мәҗбүр итә, шаярта торган. *Язмыш шаян: 1952 елның җәендә Балтыйк диңгезенең бер квадратында бик көчле шторм булып, элемтә югалды.* М.Мәһдиев

**2.** *рәв. мәгъ.* Уйнап, мәзәк белән, шукланып, шаярып яки шаяртып. *– Бу нинди чамасыз куалау? – Илһамия шаян итеп кашларын югары күтәрде.* Г.Әпсәләмов. *Яшь җитәкче буларак, мине шефлыкка алган кешеләр дә монда сирәк күренә, ярдәм итәселәре килми, дип, баягыча елмаеп, шаян гына төрттереп куйды Давыт.* М.Маликова

**3.** *и. мәгъ.* Уенчак, мәзәкчән, шук кеше. *Кайсыдыр шаяны дуңгызның түп-түгәрәк борыны астына мыек ясап куйган иде.* Аманулла

**ШАЯНЛАНУ** *ф.* 1) Шаяру, шуклану. *– Ай, күзем күрми! – дигән булды Былбыл, шаянланып.* Н.Фәттах. *Аня шаянлана, кайчак көтелмәгән, сынаулы сораулар бирә ---.* М.Рәфыйков

2) Шаянга әйләнү. *Бәти көннән-көн матурлана, шаянлана, җитезләнә, акрынлык белән генә булса да, миңа ияләнә бара иде.* Ф.Әмирхан

3) Шаянлык, шуклык хисләре белдерү, чагылдыру. *[Гыйсминең] күзләре шаянланып яна иде.* А.Шамов

**Шаянлана бару** Торган саен шаянлану

**Шаянлана башлау** Шаянлану билгеләре сизелү. *Нәни Алисә шаянлана башлады*

**Шаянланып калу** Ниндидер бер хәл, вакыйгадан соң шаянлану. *Ләкин ул яңгырның соңгы тамчысы җиргә төшеп бетмәс элек кояш чыга да бар дөньяны үзенең тылсымлы нурына күмә. Яфракларга, егылып беткән чәчәкләргә кабат җан керә. Алар кабат шаянланып калалар.* М.Кәбиров

**Шаянланып китү** Кинәт яки соңгы вакытта шаянлану. *Бозау, хуҗасының сүзен аңлагандай, тын гына тыңлап тора һәм шулай гына була күрсен дигән сыман башын чайкап ала да, шаянланып китеп, юеш танавын Зифаның битенә төртә.* Ф.Яруллин. *Гөлҗиһан бик тиз савыкты, тернәкләнде, яңадан чаяланып, шаянланып китте.* Ф.Бәйрәмова

**ШАЯНЛЫК** *и.* 1) Мәзәк, уен, шуклык. *Кызлар, Мирсәетне үртәп, үзләренең гөнаһсыз шаянлыкларын башкаларга да күчерәләр: – Егетебезнең әнисе бик усалдыр, ахрысы, кызларга карама, дип әйтеп җибәргәндер.* Ә.Баян. *Сабый булмасаң, бу чаклы Шук та булмас идең син: җир иңенә күтәралмас Мәшәкатьләр өйдең син! Синең бу шаянлыкларың Кыйммәткә төшмәс микән? Болай булсаң, берәр вакыт Авызың пешмәс микән?* Р.Миңнуллин // Шаяру чагылышы, шуклык (караштa, күзләрдә һ.б.). *Кая ул арыганлык, кая ул битарафлык! Киресенчә, бераз гына хәйлә һәм яшьләрчә шаянлык та бар иде бу караштa.* Л.Ихсанова. *Күңелеңдә шулай шаянлык, юмор булмаса, бу киңлекләрдә ялгызлыктан акылың саегуы да бар шул...* А.Хәсәнов

2) Шаян характер, шуклык, уенчаклык, мәзәкчәнлек. *Рафаэльнең шаянлыгын белгән Хәмзә абый вәкил янында Фатыйма апага бу хакта ничек кенә әйтергә дә белми аптырап тора ---.* Ф.Яхин. *Ә Яңа ел кичәсендә бер мәзәк булды, кыскасы, яңа ахирәтем үзенең шаянлыгын тагы бер кат раслады.* Г.Якупова

**ШАЯРТУ** *ф.* 1) **шаяру** I. *«Чак таптатмадың бит», – ди кыз, аны шаярта.* Ф.Кәрим. *Мөслим абыйның шаяртып сөйләвен дә аңлыйм.* Н.Фәттах

2) Үртәү, үчекләү, котырту. *Бары тик шаяртасың, иптәшләрең алдында егетне бер чәнчеп аласың гына килгәндер. Башка вакытта үртәгән кебек итеп кенә.* Л.Ихсанова. *Күрше авылга Донбасс якларыннан күченеп кайткан кибетче хатын 11 яшьлек кызчыкка: «Минем ике улым бар, шуларның берсенә кияүгә чыгарсың әле», – дип шаярта.* Н.Гыйматдинова

3) Мәзәк өчен алдалап, кешене кыен хәлдә калдыру. *– Уф! – дип, сәхнә артына кереп ауды Тимерҗан. – Болай шаяртканн өчен үтерәм Гыймади абзыйны! --- Ак күлмәкле кыз сиңа гашыйк булган, имеш.* Ф.Яруллин. *– Я, күрсәт инде «Күни» нәселен! – Мөхәммәтҗанга текәлеп өнсез калдым! Карале бу Апылыйны! Ничек явыз шаяртканн! – Мөхәммәтҗан, малай түгел шул. Кыз туды.* Г.Әдһәмова

**Шаярта башлау** Шаяртырга тотыну. *Шулай да мин, әле һаман танымагандай: – Юк, ялгышасың, брат, син күргән ул абый түгел мин, – дип шаярта башладым.* С.Сабиров. *Котбетдин тагын хатын-кызның күп сөйләшүе турында шаярта башлагач, Хөббениса түзми: – Сөйләшмибез, сөйләшмибез, дип, сез, ирләр, күбрәк тә сөйләшәсез әле! – ди.* Ш.Галиев

**Шаярта бирү** Бернигә карамый шаяртуын дәвам итү. *Ә Рәйсә ханым, шаярта биреп, сөйләвен дәвам итте: – Институтны тәмамлаган чакта, билгеле, минем дә мәгариф бүлекләрендә эшләргә исәбем юк иде.* В.Имамов. *Маннур бабагыз Ләйлә чибәргә гашыйк була да куя. Тегесе моңа карышып маташмый, җылы мөнәсәбәте белән карт гашыйкны шаярта бирә.* Г.Гомәр

**Шаяртып алу** Аз гына, бераз шаярту. *– Хатыныгызның да туфрагы уңдырышлы булса, бала-чагаларыгызны кая гына куеп бетерерсез икән? – дип шаяртып алды.* Г.Галиева. *Мине күргәч тә елмаеп җибәрде, кычкырып сәлам бирде, үзенчә шаяртып алган булды. – Бакалар бүген исерешеп беткәннәр, ахрысы, акыралар да бакыралар, – диде.* Н.Фәттах

**Шаяртып җибәрү** Кинәт шаярту; бераз шаярту. *Аңа, яратып, Дуся апа дип эндәшәләр, ул тапкыр телле дә, ара-тирә шаяртып җибәрергә дә ярата.* Кайбыч таңнары

**Шаяртып йөрү** Озак вакыт дәвамында шаярту. *Шуннан соң Мишарин*

*да: «Сез теләсәгез ни әйтегез, мин бүгенге көннән татар булдым», – дип шаяртып йөрде.* Т.Миңнуллин. *Без, студент малайлар, бик озакка кадәр: «Әтәч тагын ни эшли?» – дип шаяртып йөрдек.* Безнең гәҗит

**Шаяртып карау** Шаяртырга тырышу. *Нәрсә әйтим, мин башта шаяртып карадым, нигә син болай, анасын югалткан бозау кебек, таң иртә ялгыз мөңрисең, дим.* Г.Ибраһимов. *Бүген Сәет аның кергәненнән артык каударлануына игътибар итте. Шаяртып карарга булды: – Марҗаң янына йөри башлаганмы әллә?* Т.Галиуллин

**Шаяртып кую** Бер тапкыр шаярту. *Рафисның болай юри шаяртып куюы Ханбалның эчен генә пошырды.* Ф.Яхин. *Кайчагында үзе дә: «Мин булып мине җиндең бит», – дип шаяртып куя.* Ф.Мөслимова

**Шаяртып тору** Әле, хәзер, сөйләү моментында шаярту. *Җор телле саламчылар аны шаяртып каршы алды. Ләкин Фазылның шаяртып торырга теләге дә, вакыты да юк иде.* Н.Әхмәдиев. *Ни сөйли бу Нәфисә апа малае? Читән ярыгыннан үрелеп кычыткан да өзми торган Мансур урлашканмы? Малай актыгы, авыл исемен оятлы итеп, килделе-киттеле итеп шаяртып тормаса...* М.Шиһапов

**ШАЯРТУЛЫ** *с.* Шаярту катнаш; уен, кызык өчен генә әйтелгән, шаяртуны белдергән, шаяру сизелеп торган. *[Илсияр] үзең ярлы булсаң да, күршең бай булсын, дигән ярым шаяртулы сүзләрдә хаклык барлыгына торган саен ныграк ышана килә иде.* Ф.Яруллин. *– Укыдым бугай! – дигән шаяртулы җавапны ишеткәч: – Шулайдыр шул! – диде Хәлим.* Ф.Яхин

**ШАЯРТЫП** *рәв. к.* **шаярып**. *Иң зур сабан туйларында да ул әллә кайлардан килгән данлыклы көрәшчеләрне шаяртып кына чөеп ташлый торган булган.* Г.Ибраһимов

**ШАЯРТЫШУ** *ф. урт. юн. к.* **шаярту**. *«Менә сиңа шундый хатын кирәк!» – дип шаяртышмыйлар микән машинадагылар?* Ш.Галиев. *– Хәлимә җиңги бүген кочагында йоклаткан, ахрысы, – дип, үзара шаяртышып, сүзләре белән төрттереп калдылар.* Ф.Яхин

**Шаяртышып алу** Аз гына шаяртышу. *Казанда яшәгәндә, Исмәгыйль абый белән очрашкалый идек, шулай да узып баруынча гына булды сөйләшү, шаяртышып алулар.* Ш.Галиев. *Эш арасында әле көлешеп, шаяртышып алырга да вакыт таптылар ---.* Я.Шәфыйков

**ШАЯРУ** I *ф.* 1) Уйнау, шуклану. *--- чират Мирвәли белән Илмирага җитте, Гадел табын саклап калды. Алар тәмам хәлдән тайганчы йөзделәр, шаярдылар.* Г.Гыйльманов

2) Чынлап түгел, уйнап кына, кызык өчен, мәзәк өчен сөйләү, эшләү һ.б.ш. *Син ачуланма инде, шаярып кына сөйләшүем.* Л.Ихсанова. *--- беркөнне кәҗә тәкәсе аша сикергәндә, егылып, иренен канаткан иде шул. Егетләр шуннан көлә. Әйдә үртәсеннәр, шаярсыннар. Үртәшмәгәч, шаярмагач, тел нәрсәгә бирелгән?* Ф.Яруллин

3) Кыска гына вакыт эчендә кем белән дә булса мавыгу, кемгә дә булса гашыйк булу; берәүнең йогынтысына эләгү. *--- Гөлдери, үзе юк чакта бичәсе башка ирләр белән шаярмасын дип, больницадан һәр төн өенә шалтырата.* Г.Әпсәләмов. *[Әсма:] Шулай, син тол хатыннар белән шаярганда, мин битараф булып торырмын менә.* Х.Вахит

4) Берәр кеше белән булашу, юк-бар сәбәпләр белән бәйләнеп йөдәтү, каныгу. *Аның каравы Хөпбениса әбинең үз тугызы тугыз, зарланыпмы-зарлана: «Тапкан шаярыр кеше! Карчыклар белән шаярмасаң беткәндер шул».* Сөембикә // Кем белән дә булса үзе теләгәнчә, аның теләге һәм ихтыяры белән исәпләшмичә эш итү. *Син Платон Никитичның башына җиттең, берни булмады, әмма минем баш белән шаярма!..* Х.Камалов. *Ирек баш чайкады: – Мин аны эштән ни дип чыгарыйм? – Теләсәң, сәбәп табып була. – Нишләп мин кешенең язмышы белән шаярыйм?* Ф.Садриев

5) *сөйл.* Тигез, ритмлы эшләү сәләтен югалту; какшау. *[Вишнёв:] Төрле сүзләр белән аны кимсеттегез. Сез һәрвакытта да чиктән ашасыз. [Чебураев:] Нервлар, нервлар шаяралар минем, Степан.* Т.Гыйззәт. *Сәламәтлеге мөкиббән китәрлек булмаса да, йөрәге шаяргаласа да, ул гомеренең соңынача көрәш мәйданын ташлап чыкмады.* М.Хуҗин

6) Кирәкмәгән, зыянлы, тыелган һ.б.ш. белән шөгыльләнү, мавыгу. *Малайшалай тәмәке белән шаяра микәнни?* М.Маликова. *Тагын шунысын онытмаска кирәк: наркоманиягә бирелеп киткән яшүсмерләрнең күбесе иң әүвәл тәмәке һәм аракы белән шаяра.* З.Мәхмүди

7) Уйнау; өстән-өстән генә фикер йөртү, җиңел карау; игътибар итмәү. *Сакчы нидер мырлап бара, автоматын әсирләргә төбәгән. Бер тапкыр ул, сул күзен кысып, автоматына күрсәтте, бармак янады, янәсе, шаярмагыз.* Г.Әпсәләмов. *--- Камил дә язмышы белән шаярмаска булды, боздай суга соңгы тапкыр чумып алды да бөке булып өскә атылды.* Ф.Бәйрәмова

8) *күч.* Көлү, мыскыллау, мәсхәрәләү. *Бик авыр язмышлы кешеләр бар монда, туганкай! Язмыш шаяра адәм балалары белән. Без, күрәсең, язмыш алдында көчсез әле.* С.Поварисов

9) *юкл. форм.* **шаярмау**. Мәсьәләгә җитди, җаваплы карау. *Кабатлап әйтәм, мин яхшы апа янына килмәдем. Рәсми учреждениегә, суд рәисенә рәсми заявление китердем. Кабатлап әйтәм, мин шаярмыйм һәм шаярырга да теләмим.* Т.Миңнуллин. *Көрсенүле сүзләргә каршы яңгыраган җавап егетне бөтенләй аяктан ега язды... Өйләнәсең килсә, таң атуга яучы җибәр!.. Сиңа шаярырга гына булсын, ә мин шаярмыйм, Шәриф. Ныклап уйладым.* А.Әхмәтгалиева

10) *боер. ф. форм.* **шаярма**. Уйлап эш ит, сак кына, уйлап, абайлап сөйлә. *– Аннары нишләргә? Миңа төрмәдә утырыргамы? Шаярма, малай! Матри у меня! – дип бармак яный.* А.Хәсәнов. *Бармый хәлең юк, кыш борын төбендә генә. Фатыйма апа әйткәндәй: Шаярма, җылы як дигән белән түгел, бездә дә кыш үзенекен итә, битеңнән дә, ботыңнан да чеметә!* Р.Габделхакова. *Кызның --- йөзе җитдиләнде. Карашы кабат Харисның күзләрендә беректе. – Шаярма, Харис! Көлмә минем хисләремнән, зинһар.* А.Фәләх

11) *күч.* Төрле юнәлештә бик тиз хәрәкәт итү, нәрсәне дә булса хәрәкәтләндерү. *Җил шаяра, җил котыра, Күгәрчен кебек гөрли ---.* Р.Вәлиев

**Шаяра башлау** Шаярырга тотыну. *Мичманның хәле шактый яхшырган, ул инде көлә, шаяра башлаган.* Г.Әпсәләмов. *Тимербулат җәймә буйлап үрмәли, көлә, шаяра башлады.* М.Маликова

**Шаяра бирү** Бернигә карамый шаяруын дәвам итү. *Ир --- барып җитүгә, шаяра биреп, биленнән алды, көлеп әйтте: – Ясаган иям үземә катынның тәверен бирде гуй: син минем артымнан килдеңме? – диде.* Г.Ибраһимов

**Шаяра төшү** Бераз шаярган кебек итү. *– Әй, иптәш Ринат, – дип, шаяра төшеп, әмма үз итеп дәште ул миңа гел уйламаган-көтмәгәндә.* Р.Мөхәммәдиев. *Заһидә, үгет-нәсыйхәтем күпкә*

*китте диптер инде, шаяра төшеп, Әхмәтсафаның җиңеннән тартып куйды.* Ф.Сафин

**Шаярып алу** Аз гына, берникадәр шаяру. *Рөстәмдә балалык шуклыгы кузгалды, шаярып аласы килде.* Г.Кутуй. *Тәгаен Рая Хәмидуллина инде бу. Бераз шаярып алмаса, бер-бер хикмәт уйлап чыгармаса, күңеле булмый аның.* В.Нуриев

**Шаярып йөрү** Хәзер яки билгеле вакыт дәвамында шаяру. *Гел шундый бул, без синең уйнап-көлеп, шаярып йөрүеңә ияләнгән.* Г.Галиева. *Ул яшьләр арасында, берни белән дә аерылмыйча, уйнап-көлеп, дусларча шаярып йөри.* И.Юзеев

**Шаярып калу** Шаярырга өлгерү. *[Ләйсән:] Кияүгә чыкканчы шаярып кал, дип әйткән ди бер акыл иясе.* Ф.Яруллин. *Балачакта ял итеп, уйнап, шаярып каласы килә инде ул.* Ватаным Татарстан

**Шаярып карау** Шаярырга тырышу. *– Ну, Солтан абый, икебезгә дә ата бул: безгә фатиха бир, – ди. Мин шаярып карадым, бу эштән читтә калырга җай калмады, кычкырып көлдем: – Ике яшькә мәхәббәт телим, – дидем дә кулларын кыстым.* Г.Ибраһимов. *Кече кызымның ире – айныткыч нәчәлниге! Шаярып кара син минем белән!* Ф.Баттал

**Шаярып кую** Сирәк-сирәк яки бер тапкыр шаяру. *Оныгының әле генә әйткән сүзен ул чынга алмады алуын, торып-торып шулай әбисе белән бер шаярып куя торган гадәте бар аның, әле шулай гынадыр.* Л.Ихсанова. *Күрше читлекләр эчендә селәүсеннәр --- утыра. – Болары минем балаларым инде, – дип шаярып куя Салихҗан.* Я.Шәфыйков

**Шаярып тору** Әле, хәзер, сөйләү моментында шаяру; һәрвакыт, еш шаяру. *[Кирам:] Минем синең белән гел шаярып торасым килә, матурым.* Ф.Яруллин. *Язмыш кешеләр белән даими шаярып тора.* С.Поварисов

**Шаярып яту** *сөйл.* Гел шаяруда гына булу. *--- болында башларына абыйлары, әтиләре алып кайткан иске шляпалар кигән авыл малайлары атлар көтеп шаярып яталар.* Һ.Такташ

**ШАЯРУ** II *и.* 1) Көлке, кызык, шаянлык; күңел күтәрә торган, кызык табу өчен эшләнгән эш, кыланыш, әйтелгән сүз һ.б. *Ләкин бу төрткәләшүләр торабара дусларча шаяруга гына әйләнеп калды.* Г.Сабитов. *Бусы Рөстинең шаяруы иде. Аның шаяруы һәрвакыт шулай хәзерлексез, юморсыз һәм дорфарак килеп чыга.* Г.Рәхим

2) Кешедән көлү; мәсхәрә, мыскыл. *Чыраемны күреп кешенең коты очмасын дип, шулай яшерендегез. Тукайның ярым шаяруы, кырыс шаяруы ханымга көчле тәэсир итте, ул: «Аh, сез усал Тукай!», – диде.* Р.Батулла. *Яшьлек юлләрлегенә язмышның ачы шаяруы да өстәлгәндер: төркем белән көчләүдә гаепләнелгән егетләрнең өчесен дә төрмәгә утырттылар.* Д.Бәдриев

**ШАЯРУЛЫ** *с.* Шаяру катнаш, уйнап кына әйтелгән; шаянлык, шуклык сизелеп торган. *Баш хирург һаман шаярулы мөлаем йөзле иде.* Х.Камалов. *Сәрия, шаярулы тонга күчеп, йөзенә елмаю чыгарды.* Ф.Садриев

**ШАЯРУЧАН** *с.* Шаярырга һәвәс, шаярырга яратучы, шаян. *Бичураның кайберсе шулай бик шаяручан булганга, өйдә торырлык чама калмагач, хуҗалары өйне бөтенләй дә ташлап китәләр.* Әкият. *Бу дөньяда бар кеше дә үлеп яраткан кешесе белән генә яшәми, язмыш, аерата яшь чакта, шаяручан, алдаучан һәм шул ук вакытта алданучан була.* М.Хәбибуллин

**ШАЯРЫНУ** *ф.* 1) Шаяргалау, уйнау, уйнаклау. *Шаярынсаң, уйнасаң да, Кулга кулны бирсәң дә, Әлләниләр уйласаң да, Сөям, көям, дисәң дә – Күгәрченем, ышаналмыйм, Рия түгел микән соң?* М.Җәлил. *Мондый хәлдән соң уенны дәвам итик, дип шаярыну килешми иде инде.* З.Мурсиев

2) Җиңелчә генә шаярып алу, бераз шаярту. *[Шәңгәрәй:] Эчмәгән кешене бик яратам мин! – дип шаярынашаярына, аракы шешәсен өстәл астына, үз аягы янына куйды.* Г.Ибраһимов

**ШАЯРЫП** *рәв.* Җиңел генә, әллә ни зур көч куймыйча, уйнап кына, ансат кына. *Николай --- туфрак эшен бик файдалы тапкан, шаярып кына сиксән тиен, бер сум төшерәсең ди.* Ш.Камал. *--- Газинур учларын бер-берсенә ышкып, атлагычка тотынды. – Карап карыйк әле, нигә чыгымлый икән ул. – Кызлар Газинурның эшен кызыксынып күзәтә башладылар. Ул, бер дә көч куймый, шаярып кына эшли кебек.* Г.Әпсәләмов

**ШАЯРЫШУ** *ф. урт. юн. к.* **шаяру**. *Менә алар буа өсләп бирге якка чыктылар, аякларын чишенеп, озаклап, шаярышып юындылар.* А.Гыйләҗев. *Бер-беребезгә күз уйнатып, хәтта каш сикертеп шаярышабыз.* А.Хәсәнов. *Шаярыша казлар дулкын белән, Киек юлдан очар чак җиткән.* В.Фатыйхов

**Шаярыша башлау** Шаярышырга тотыну. *Алар төрлечә шаярыша башладылар.* Ф.Яруллин. *Тәнәфестә коридорга чыгып өлгергән малайлар шаярыша башлады.* Р.Кәрами

**Шаярышып алу** Кыска вакыт эчендә шаярышу. *Кайберәүләр, эчләренә төшкән салкыннан котылырга теләп, --- үзара шаярышып алгандай итәләр.* М.Хәсәнов. *Үсмер онықлары – Диана һәм Айнур – бераз чырык-чырык килешеп, тарткалашып, шаярышып алдылар ---.* Х.Мөдәррисова

**Шаярышып тору** Даими рәвештә яки әле, хәзерге моментта шаярышу. *Кайда монда алай шаярышып тору, дөньяда җитдирәк хәл-әхвәлләр кузгалып китте, уен-муен корып торырга вакыт тимәдә.* Ф.Хөсни. *Өйдә күнегеп, шаярышып торган малайлар трамвайда, үзләренең «сала кабартмалары» икәнлекләрен хәтерләп, посыбрак, тын гына бардылар.* А.Гыйләҗев

**ША́ЯТЬ** *кер. сүз* Сөйләүченең үз фикеренең чынлыгына, дөреслегенә карата бераз шикләнүен, ләкин булу, үтәлү мөмкинлегенә өмет итүен белдерү өчен кулланыла; бәлки, ихтимал, шәт. *Инде кызыл түйда утыру бәхетенә дә ирештем. Шаять, монысы соңгысы булмас.* Г.Әпсәләмов. *Иренең балага да, үзенә дә йомшарып, игътибарлы булып китүе үлән тамчыларына карағанда, шаять, мең мәртәбә шифалырак булгандыр.* Г.Галиева

**ШӘБӘЙТҮ** *ф. йөкл. юн. к.* **шәбәю** (*1–2 мәгъ.*). *Ничарадан бичара, сугыш коралларын шәбәйтергә тиешле Нәҗип мал-туар белгече булып китте.* А.Гыйләҗев. *Сәхия адымнарын шәбәйткән саен, ак костюмлы кепи дә кызулый барды.* Ф.Яруллин. *Вакыт үз артыннан ияртә. Мизгелләрне кушакуша җыеп, Еллар әйләнешен шәбәйтә.* Ф.Дәүләтгәрәева

**Шәбәйтә бару** Торган саен ныграк шәбәйтү. *Поезд, йөрешен шәбәйтә барып, шагыйрьне сөекле Казанына таба алып китә.* И.Нуруллин

**Шәбәйтә төшү** Бераз шәбәйтү; тагын да шәбәйтү. *Сүзлек төзүне шәбәйтә төштек*

**Шәбәйтеп җибәрү** Кинәт шәбәйтү. *Ә инде матурлыгына күпләрнең күзе төшүе Катифәнең эчкә яшеренгән горурлыгын, хәтта нәселләрендә әтисе*

*ягыннан килгән мин-минлеген шәбәйтеп җибәрә иде.* Р.Сибат

**ШӘБӘКӘ** *и. гар.* Азәрбайҗан һәм Якын Көнчыгыш илләре архитектурасында агачтан (кайчак тимердән яки таштан) эшләнгән бөтен яки җыелма челтәрле тәрәзә рәшәткәсе

**ШӘБӘРҮ** I *ф.* Суда, яңгырда бик нык чылану, җебенү, юешләнү; чыланып кыяфәтне югалту. *Алар, суга манып алгандай, шәбәреп кайтып керделәр.* Ф.Яруллин. *Авылга сирәк кайтып, уклау йоткан кебек гәүдәне төз куеп, вәкарь белән генә сөйләшеп йөргән Мәрдиевнең кыяфәте бүген шәбәргән әтәчкә охшап калган иде.* М.Галиев

**Шәбәреп бетү** Тәмам, тулысынча, ахыргача шәбәрү. *Ишек катында Мидхәт басып тора иде. Костюмнан гына, тәмам шәбәреп беткән, чөнки курткасын салып, кулындагы баланы төргән.* М.Маликова. *Мондый көнне юлга чыгалар димени, --- бигрәкләр дә шәбәреп беткәнсең бит.* Ф.Яхин

**Шәбәреп калу** Ниндидер бер сәбәптән соң шәбәрү. *Баш врачыбыз өстенә салкын су сипкән тавыктай шәбәреп калды һәм мескен тавыш белән: «Комиссия арты комиссия. Кемгә ярарга да түгел», – дип зарланды.* Ф.Яруллин

**ШӘБӘРҮ** II *ф. диал. к.* **шәбәю**. *[Әгъләм] башта әй шәбәргән, әй тасма телләнгән иде. Ул бер ел эчендә колхозда бөтен эшне дә ал да гөл итәчәк иде.* Р.Төхфәтуллин. *Сихерче Лахсай бер-ике көн Кирмән Каланы, Аксарайны, уеннарны карап, --- ширбәт эчеп шәбәреп йөрде дә --- хуҗасы Бузмах янына кайтып китте.* Р.Батулла

**ШӘБӘЮ** *ф.* 1) Нинди дә булса эшхәрәкәтнең, процессның башкарылу интенсивлыгы арту, тагын да көчәю. *Яңгыр бер азайган кебек була, күк күкрәгәч, тагы шәбәеп яварга тотына иде.* Х.Камалов. *Җиле дә сәер: бер мәлгә кайдадыр посып тора да аннары йөзгә иркәләп кагыла, тагын тына һәм элекке юнәлешенә каршыдан шәбәеп исәргә тотына.* М.Хуҗин

2) Тизлеге арту, кызулау. *Поезддан төшкәндә, аякларын көчкә-көчкә сөйрәп чыккан ананың, госпитальгә якынлашкан саен, адымнары шәбәйде.* Ф.Яруллин. *Нурислам, атыңны җәһәтрәк атлат әле, аңа карап без дә шәбәябез бит.* Ф.Садриев

3) Тагы да яхшырак, әйбәтрәк хәлгә килү, яхшыру; камилләшү. *Мехчы абзагызның матди ягы да бер ай эчендә диярлек шәбәйде: кырык сум да алтмыш сум – барлыгы йөз сум, ә ул заманда бу шактый зур акча иде.* Ә.Еники. *Фронтта, ичмасам, ашау кайгысы булмады: армия тук иде. Өсбаш Сталинград сугышы алдыннан бик шәбәйде.* М.Мәһдиев

4) *күч.* Масаю, үзен эре тота башлау, һавалану. *Чат Шәрәфинең җебегән Әсмасы да, Яраслауда торфта эшләп кайткач, кем булып шәбәеп, һаваланып йөргән иде.* А.Гыйләҗев

5) *күч.* Батыраю, кыюлану, үзендә көч-куәт сизү. *Яшь булмасак та, бер дә алардан ким дә түгел. Күңеленнән шулай шәбәйсә дә, баштарак җиңел атласа да, кояш югары күтәрелеп көнне кыздыра барганда, саилче арый, йончый башлады.* Н.Фәттах. *Гатыев сөйләгәндә шәбәя, гайрәтләнә. Алдында яткан кәгазьләргә карамый.* Х.Камалов

**Шәбәя бару** Торган саен шәбәю; һаман шәбәю. *Ул үткәннәрдән сүнми калган зәгыйфь очкын иде. Очрашып сөйләшкән саен шәбәя барды.* Х.Камалов. *Аның җыры телдән телгә, күңелдән күңелгә күчеп үзгәрә, шәбәя барган.* К.Тимбикова

**Шәбәя башлау** Шәбәергә тотыну. *Ул арада яңгыр шәбәя башлады.* Н.Фәттах. *Гел көньяк-көнбатыштан исеп торган җил, юнәлешен үзгәртеп, төньяктан шәбәя башлады ---.* Г.Әпсәләмов

**Шәбәя төшү** Бераз шәбәю; тагын шәбәю. *Күрше бүлмәдәге сүзләр башта әкрен-әкрен генә, тора-бара шәбәя төшеп, дәвам иттеләр ---.* Ә.Фәйзи. *Картәнисе генә, оныкасы тәрбиясендә бераз шәбәя төшү белән, тизрәк туган авылына --- кайтырга ашкына.* Кызыл таң

**Шәбәеп алу** Кыска вакытка шәбәю, бик тиз шәбәю. *Шәбәеп алган «эшем кешеләре» тышта тагын күпмедер вакыт тавышландылар да юлга чыктылар.* И.Хуҗин

**Шәбәеп калу** Ниндидер бер вакыйгадан соң шәбәйгән хәлгә килү; шәбәергә өлгерү. *Шулай да Туфайловның эченә җылы керде, безнекеләр алга киттеләр дип иркенәеп, шәбәеп калганын тойды.* Х.Камалов. *Җәй урталарында чак күренеп торган камышлар августта су төшә башлауга озынаеп, шәбәеп калалар, керсәң чыга алмаслык урманга әйләнәләр.* А.Гыйләҗев

**Шәбәеп карау** Шәбәергә омтылу. *Дөньяны иңләп алырдай булып, күкрәк сугып, тузынып, әтәчләнеп, нинди шәбәеп йөри торганыең син яшьрәк чакларыңда. Шәбәеп кара хәзер – сиңа илле яшь.* Н.Фәттах

**Шәбәеп китү** Кинәт кенә, ниндидер моменттан, сәбәптән соң шәбәю. *Ә торабара минем эшләр тагын да шәбәеп китте: төштән соң, җиңги амбарда вакытта, --- Фәрзетдиннәр белән чана да шугалый башладым.* В.Нуруллин. *Карап-карап торам да, бик шәбәеп киттең әле син.* М.Хәсәнов

**ШӘББУЙ** *и. фар. бот.* Әвернәчәчәклеләр семьялыгыннан төрле төсләрдә хуш исле чәчәк ата торган күпьеллык декоратив үсемлек; *русчасы:* **левкой**. --- *шәббуй, ахшам миләүшәсен төнге күбәләкләр серкәләндерә.* Л.Мәүлүдова. *Эт какысы, кәбестә, редиска, шалкан, торма, гәрәнкә, шәббуйның җимешләре кузакча формасында.* Биология

**ШӘГЪБАН** *и. гар.* Ай елының сигезенче ае исеме. *Шәгъбан аеның 15 нче көненә каршы төндә яфракларына якты дөньдагы кешеләрнең исеме язылган тормыш агачы селкенә дә исеме язылган яфрак коелып төшкән кемсә шушы ел дәвамында үләчәк диган ышану бар.* А.Тимергалин

**ШӘЕХ** *и. гар.* 1) Берәр тарикатькә кереп барлык рухи үсеш юлларын үткәннән соң шул тарикатьнең башы булырлык югары дәрәҗәгә ирешкән һәм үзенә мөрид (дәрвиш) үстерү рөхсәте бирелгән кеше; пир, ишан. *Шәехнең бер гадәте бар иде: тәсбихен биленә баглап йөрер иде.* К.Насыйри. *Бохарадагы ике йөз мәчет имамы өчен остаз һәм мөхтәсиб булып торган Мәҗит шәех бер сәгатьтән соң Таш-арка эчендәге дар агачында җан тәслим кылды.* В.Имамов

2) Билгеле бер территория хөкемдары яки күчмә кабиләләр башы. *Сәгыйдь, моны күрү белән, үзләренең Гарәбстандагы гаширәт башындагы шәех урынындагы кеше икәнен аңлады.* Г.Гобәйдуллин. *Йосыф таулыларның легендар башлыклары шәех Шамил улы белән дә очраша.* М.Хәсәнов

3) Гарәп илләрендә: ыру башлыгы, җәмгыятьтәге аксакал, әмир. *Әллә каян гына Газиз шәех атлы әмир табылды да, шул килмешәк Морад гомерен кыйды.* В.Имамов

4) Мөселман руханиларының иң югары вәкиле; илаһиятчы галим һәм фәкыйһ. *Шәех Равил Гайнетдин Мәрҗани мәчетендә вәгазь укыды*

5) *күч.* Нинди дә булса бер һөнәрчелектә югары осталыкка ирешкән, остаз

булырлык кеше. *Г.П. Снесарев бу хакта бераз башкачарак яза: Зәнки атаны ул шәех дип атый, аның бөтен Урта Азиядә мөгезле эре терлек көтүчеләренең пире – яклаучысы һәм саклаучысы булуын күрсәтеп үтә.* Татар мифологиясе

**ШӘЕХЛЕК** *и.* Шәех вазифасы; шәех дәрәҗәсе; шәех булу хәле. *Бервакыт Әхмәд Ясәвинең мөридләре, үзләрен җитлеккән галим дип санап, остазларыннан шәехлеккә фатихасын сорый башлаганнар дип сөйлиләр.* А.Тимергалин

**ШӘҖӘРӘ** *и. гар.* Нәсел чылбырының кемнән башланып, тармакланып китүен, үсүен күрсәткән схема; нәсел агачы. *Әбинең Коръәне кырыйларына безнең шәҗәрә язылган иде: минем әти Әхмәтша, аның әтисе, минем бабай, Мөхәммәтша булган.* Г.Әпсәләмов. *Мөхәммәд галәйһиссәламнең егерме буынга кадәрле нәсел шәҗәрәсе билгеле.* А.Тимергалин

**ШӘЙ** *и. гар. иск.* Әйбер, нәрсә. *Мантыйк ноктаи назарыннан карағанда, ул кадәр пошиман булырлык шәй юк* ---. Т.Гыйззәт. *Тагын шунысы да килеп чыга: дөнья, дөньядагы һәр шәй минем өчен бер нәрсә, ә башка берәү өчен бөтенләй икенче нәрсә.* Р.Әхмәтьянов

**ШӘЙГӘ** *бәйл. к.* **шәпкә**. – *Нишләп сөрсеп ятыйм, ди! Минем дә ял менә дигән булды – диде ул, каклаган каз ботын бик тәмләп чәйнәгән шәйгә.* Э.Касыймов. --- *малай, энесеннән кулын ычкындырып атлаган шәйгә, муены каерылганчы әллә ничә тапкыр артына борылып карады.* А.Әхмәтгалиева

**ШӘЙЛӘҮ** *ф.* 1) Күз ярдәмендә нәрсәнең дә булса барлыгын тою, тоныкына күрү, абайлау. *Баганадан төшкән ут челтәре аша бик куе томан булуын шәйләделәр.* Х.Камалов. *Йомылган күзләрен куллары белән дә каплаган иде Саттар, әмма станция эчендәге көчле яктылыкны барыбер шәйләде.* Ф.Баттал // Ачык күрү, детальләрен аеру. *Көн яктысыннан келәт эченә килеп кергәч, башта бернәрсә шәйли алмыйча тордым.* Ә.Еники. *Күзгә төртсәң күренмәс төннең караңгылыгына ияләшеп өлгерсә дә, андый-мондый чит шәүләләр барлыгын шәйли алмады.* Ф.Яхин

2) Нәрсәне дә булса сизү, тою; читләтеп белү. *Бу темалар чәйнәлеп бетеп башка язар бизәкләр калмаганга, мин, аларның бары берме, икеме юлын укуга ук, эшнең нидән торганын шәйли идем.* Р.Сәгъди. *Мин, юлга чыгып бераз бару белән, артыбызга бер «Волга» тагылганын шәйләдем.* Ф.Яруллин // Кемнең дә булса уй-фикерен, ниятен, хәлен чамалау, төшенү, аңлау. *Сизә Наилә, бу уйларның үз файдасына түгеллеген шәйли, ләкин, чирле ир хатыны буларак, бүтәнчә уй йөртә алмый.* А.Гыйләҗев. *Алексей аның чын күңелдән әйтми бит бу, дип уйлавын шәйләгәндәй булды.* Х.Камалов

3) *күч.* Ахыргача аңлау, белү. *Әлбәттә, шигырь тәрҗемәсендә вакыйга булырлык мондый зур хезмәттә без шәйләп бетермәгән җитешсезлекләр дә булырга мөмкин.* Р.Фәйзуллин

**Шәйләп алу** Тиз арада, кыска вакыт эчендә шәйләү. *Шулчак Гәрәй тиздән бу пароход белән саубуллашырга туры киләчәген шәйләп алды* ---. С.Сабиров. *Урамның каршы ягында --- каккан багана кебек басып торган адәм затын шундук шәйләп алды ул.* Г.Гыйльманов

**Шәйләп бетерү** Бөтенесен дә, барысын да шәйләү. *Күзләрем дә бик шәйләп бетерми.* Г.Сабитов

**Шәйләп җиткерү** *к.* **шәйләп бетерү**. *Вакыты белән вәгъдәгә юмартланып ташлавы бар: теге яки бу шөгыльнең аңардан гына тормаганлыгын бәяләп, шәйләп җиткерми.* Т.Галиуллин

**Шәйләп калу** Шәйләргә өлгерү. *Кунакның тизлек, җәһәтлек, саллылык белән алдырганын Ярулла шәйләп калган була* ---. Т.Галиуллин. *Хәлим телсез әпә күкрәгендә бер уч кадәрле генә шәрәлек шәйләп калды.* Г.Гыйльманов

**Шәйләп тору** Хәзер, шушы вакытта яки һәрвакыт шәйләү. *Икесе дә тын калып, снарядларның кая юнәлгәнен бөтен тәннәре белән сейсмограф шикелле шәйләп тордылар.* Х.Камалов. *Син күрмәдең, ә мин сезнең барчагызны да базар читендәге бер чатыр түбәсеннән озак шәйләп тордым.* В.Имамов

**Шәйли башлау** Шәйләрлек дәрәҗәгә җитү. *Ляшков --- караңгыга күзе ияләнгәч, часовойны бик яхшы шәйли башлады.* Х.Камалов. *Текәлебрәк карагач, Әмир бик шыксыз күренгән, ярлы гына киенгән карчыкта элеккеге гүзәлләрнең гүзәле Сәвия чалымнарын шәйли башлады.* Т.Галиуллин

**Шәйли төшү** Бераз шәйләү, тагын да шәйләү. *Килеп җитәрәк ташның чүкеп уелган тоныкязуын, сурәтен, өске уң почмактагы йолдыз рәсемен шәйли төште.* Ә.Гаффар

**ШӘЙХЕЛИСЛАМ** *и. гар.* Мөфтиләргә, гомуми кабул ителгән илаһият белгечләренә бирелә торган шәрәфле титул һәм шул титулга ия зат. *Русия Үзәк диния нәзарәте рәисе, баш мөфти шәйхелислам Тәлгать Таҗетдин моннан соң айга бер тапкыр Казанның төрле мәчетләрендә җомга намазын алып барачак.* Безнең гәҗит

**ШӘЙШЕ** *и. а.х.* Конус формасында сөялгән ботаклы агачлардан гыйбарәт, өстенә көлтәләр, печән, салам кебек нәрсәләрне киптерү өчен хезмәт итә торган терәк; шеш. *Безнең туры ат Урыс Кәрим дигән кешенең тары җиренә кереп, аның бер шәйшесе янында тора. Шәйшенең бер ягын актарып төшергән.* М.Гафури

**ШӘКЕЛ** *и. гар.* 1) Форма. *Мөслими Җирнең яссы булуы турындагы хорафатны кире кага, аның шар шәкелендә булуын дәлилли* ---. А.Тимергалин. *Изүе ачык. Сул як яка төз тора. Уң яктагысы өчпочмак шәкелендә кайтарылып төшкән.* С.Поварисов

2) Сын, тышкы күренеш, кыяфәт, рәвеш. *Табигать миллионлаган еллар дәвамында планетабызда үсемлекләрнең күптөрлелеген тудырган, аларның һәркайсына буй, гәүдә, шәкел, төс һәм башка сыйфатлар сайлаган.* К.Гыйззәтов

3) Сызык, схема; охшатып ясалган фигура. *Шахмат шәкелләрен ул да Димәшкъ каласыннан китертте, һәр шәкелгә алтын белән түләде.* М.Хәбибуллин

**ШӘКЕЛМӘ** *и.* 1) Логарифмик линейка шкаласы буйлап күчерелеп йөртелә торган күрсәткеч җайланма. *Син линейкаңның шәкелмәсен генә бармак башы белән әрле-бирле шудыртасың.* Г.Әпсәләмов

2) Аркан белән бергәләп елым тартканда ләмкәне арканга элэктерә торган җайланма. *Диңгез ягасыннан утызкырык сажинлап читтә аркан җыела. Шушы чиккә җиткән бер кеше кире кайта да диңгез янында ук арканга үзенең шәкелмәсен элэктерә.* Ш.Камал

3) *диал.* Туку станында тәбелдерек

**ШӘКЕРТ** *и. фар.* 1) Мәдрәсә укучысы. *Күпмедер вакыт Харәземдә һәм Казан артындагы Казаклар, Кышкар мәдрәсәләрендә шәкертләргә белем биреп, байтак тәҗрибә туплаган шагыйрь --- Каргалыга килеп төпләнә.* М.Маликова. *Элек укыган мәдрәсәсендә Вәлинең --- шәриге һәм иң якын күргән иптәше Васыйх исемле бер шәкерт тора иде.* Гали Рәхим

2) Гомумән укучы. *Сулф тарафдарлары, татар театр техникумы шәкертләре милли сәнгать өчен яңа булган шартлы-метафористик театр принципларын пропагандалаучы спектакль-тамашаларын бер-бер артлы тамашачыга тәкъдим итә.* Гасырлар авазы. *Ширкәт түрәләрен Татарстан президенты кабул итте, алар шулай ук КФУ шәкертләре белән дә очрашты.* Татарстан яшьләре

3) Берәр тәгълиматны, кемнең дә булса эшен дәвам иттерүче; өйрәнчек. *Ул – татарлардан беренче врачларның берсе, --- мәшһүр медик Казембекның һәм башка Казан профессорларының иң сәләтле шәкертләреннән берсе.* Г.Әпсәләмов. *Үзе дә дөньякүләм танылган шахматчы Рәшит Нәҗметдиновның шәкерте бит ул, уенның бөтен кагыйдәләрен үзләштергән бер дигән шахматчы.* В.Нуриев

**ШӘКЕРТЛЕК** *и.* Шәкерт булу хәле; шәкерт булган чор. *Ф.Әмирхан шәкертлек елларыннан ук үзен яңалык тарафдары итеп күрсәтә башлаган ---.* М.Хәсәнов. *Әмма теге яки бу йогынтыга бирелгән очракта да ул остазлары алдында таләпчән шәкертлек холкын күрсәтә алган ---.* Г.Морат

**ШӘКЛИ** *с. гар.* 1) Формага караган, форма ягына гына игътибар иткән

2) Форма тәгълиматына караган, морфологиягә караган, формаль. *Г.Алпаров «Шәкли нигездә татар грамматикасы» китабында татар фигылен өч төркемгә бүлә ---.* Фән һәм тел

**ШӘЛ** *и. фар.* Бәйләнгән яки тукылган зур баш яулыгы. *Тик Ләлә Мәхмүтовна гына, артык дәшмичә, зифа буен җылы мамык шәленә төреп, стенага сөялгән көе, сын кебек торды.* Л.Ихсанова. *Хәзергедәй күз алдында Рәүфнең: сумкасын болгап, башындагы ефәк шәлен җилфердәтеп йөгереп менде ул.* М.Маликова

**ШӘЛЕ** *и. фар.* Ярдырылмаган, эшкәртелмәгән, гадәттә чәчүлек дөге

**ШӘЛПӘЮ** *ф. к.* **шәлперәю**. *Карабодайның да берәм-сәрәм зәгыйфь яфраклары шәлпәеп төшкән.* Ш.Маннур. *Курку белмәс юеш Бурзай Үз оясына керә... Йон шәлпәйгән, сырт бөкрәйгән – Күгәрченкәй чыланган.* И.Биектаулы

**ШӘЛПЕГАВЫЗ** *и. сөйл.* Ачыгавыз, мәмиавыз; жебегән, булдыксыз кеше

**ШӘЛПЕК** *с.* Шәлперәйгән, шәлперәеп, салынып төшкән. *Шәлпек иреннәре, яше олыгаюына карамастан, һаман да шул килеш, чәй эчкәндә, стаканның яртысына диярлек җитеп сәлперәеп торалар.* М.Хуҗин

**ШӘЛПЕРӘЮ** *ф.* 1) Шиңү, сулу. *Корылык килсә, озак вакытлар яңгыр тамчысы төшмәсә, иң элек декоратив үсемлекләр сула. Вакытында тәрбия күрсәтмәсәң, шәлперәеп төшә, шиңәләр, бичаракайлар.* Р.Низами. *Беренче кыраудан ук шәлперәйгән чәчкә кебек мәлҗерәве, төшенкелеккә бирелгәне өчен, үзен тиргәп ташлаган чаклары да булгалый.* М.Хәсәнов

2) Һавасы чыгып яки башка сәбәптән тыгызлыгы бетү; шилү. *Туп шәлперәю*

3) Сузылып яки тартылып аска таба салыну, түбәнгә таба асылынып тору. *Тик бу бәхетле кеше бурзайларның әле берсенең, әле икенчесенең озын йонлы муенын кытыклап уйный, шәлперәйгән колакларын, очлы борыннарын угалап шаяра ---.* А.Вергазов. *Аларның күзләре калайланып тонган, куллары хәлсез шәлперәйгән, гәүдәләре печән өеме кебек ишелеп төшкән иде.* Ф.Бәйрәмова

4) Тән тиресе тыгызлыгы бетү сәбәпле озаю, салынкылану, сәлперәю. *Кабарынкы күз кабаклары тагы да салына төште. Хәтта шешенке бит тиреләренә кадәр шәлперәйде сыман.* М.Хәсәнов

5) Чирләү, картаю һ.б. сәбәпләр аркасында хәлсезләнеп зәгыйфьләнү. *Шәлперәеп төшкән карт директор көч ягыннан минем белән ярыша алмый, һәрхәлдә.* Ш.Алпар. *Эчә башлаганчы, бик көчле, зур, матур кеше иде Камилнең әтисе, хәзер генә бетереште, шәлперәйде, хәлсезләнде.* Ф.Бәйрәмова

6) *күч.* Хәлдән таю, рухи һәм физик изелү. *Бөтен гәүдәсе хәлсезләнеп, шәлперәеп төште.* Казан утлары // Ачуы басылу, гайрәте шилү. *Тыгыз матур гәүдәсе дә зифалыгын җуеп, шәлперәеп төште.* М.Әмирханов

7) *күч.* Ихтыяр көче киту, төшенкелеккә бирелү, кәеф китү. *Нәҗипнең боек күңеле тагын да шәлперәйде.* А.Гыйләҗев

8) *күч.* Нинди дә булса хәл алдында юашлану, курку, каушау, жебеп төшү. *Ир каршысында --- Себергә куылган татарның кызы иде. «Дөньялары тар булса да булыр икән!» димичә, ни диясең инде бу хәлләрдә. Тик шәлперәеп төшү ярамас.* Р.Гаязетдин

**Шәлперәя башлау** Шәлпәергә тотыну. *Ишегалды да кысрык – тупка тибәсең һәм шәлперәя башлаган тубың берәрсенең тәрәзәсенә оча да куна һәм... чылтырт!* М.Хуҗин

**Шәлперәя төшү** Беркадәр, бераз шәлперәю; тагын да шәлперәю. *Габделхәйнең гәүдәсе дә шәлперәя төшкән, күзләре чак кына кызарган, карашында коры зәһәрлек тә бар сыман.* Э.Касыймов. *Аның сүзләре дөрес иде, бар да тын калды, Исхак та йомшады, шәлперәя төште.* Р.Батулла

**Шәлперәеп бетү** Бөтенләй, тәмам шәлперәю. *Нигә кирәк ул шәлперәеп беткән чәчкә.* Р.Мулланурова. *Ишек ачылып китә, Кәрлә карт түргә үтә. Бетсә дә шәлперәеп, Кычкыра кәперәеп.* Х.Җәләй

**Шәлперәеп калу** Ниндидер вакыйгадан, тәэсирдән соң шәлперәйгән хәлгә килү. *Түп-түгәрәк булып тулып килгән җилен бөтенләй шиңеп, шәлперәеп калган.* А.Хәсәнов

**Шәлперәеп килү** Соңгы арада шәлперәю, шәлперәюе күренә башлау. *Аның тулы, түгәрәк гәүдәсе коры сөяккә калган, яңаклары суырылып, шәлперәеп килгән, эчкә баткан күзләрендә бер дә бетмәс хәсрәт һәм газап.* Ф.Бәйрәмова

**Шәлперәеп китү** Көтмәгәндә, кинәт шәлперәю. *--- егетнең тез буыннарына хәтле йомшады. Бөтенләй шәлперәеп китүдән куркып, сүзсез генә --- утырды.* А.Хәсәнов

**Шәлперәеп тору** Гел шәлперәйгән хәлдә булу

**ШӘЛЬЯУЛЫК** *и.* Матур чәчәкбизәкләр төшерелгән, йоннан тукып эшләнгән зур баш яулыгы. *Зәйтүнә, бизәкле шәльяулыгын салып, агач караватбашына элде ---.* Г.Ахунов. *Октябрь урталарында ул төш күреп уянды: әтисе сәкедә утырган Бибиямалның иңнәренә алсу кызыл гөлҗимеш чәчәге төшкән озын чуклы ак шәльяулык салды ---.* Р.Хәбибуллина

**ШӘМ** *и. гар.* 1) Парафинның яки берәр төрле майлы матдәнең уртасына филтә кыстырып ясалган таякчык формасындагы яктырту әйбере. *Ярымкараңгы залда шәм яктысында ресторанда утырабыз.* М.Мәһдиев. *Кәстрүл, Шомбай бүреге сыман, идән буйлап тәгәрәп китте, шәм мае, чәчрәп, келәмне агартты.* Х.Ибраһим

2) *иск.* Яктылык көчен үлчәү берәмлеге

3) *тех.* Эчке янулы двигательне кабызу системасында очкын бирү детале. *Шәмнәрне тикшерү. Кабызу шәме. Кыздыру шәме*

4) *тех.* Нефть скважинасына төшерү өчен берничәсен ялгап ясалган озын торба. *Моннан инде барасы буровойның сәндерәсе дә, андагы верховойның гәүдәсе дә аермачык булып күренә иде. Ахры, бораулаучылар инструмент күтәрәләр – верховой шәмнәрне кабул итәргә менгән.* Ш.Бикчурин. --- *ярты-шар тонналы озын-озын торбаларны буровойга кул белән сөйрәп кертәсе юк: аларны механизмнар тарттыра. Шәмнәрне утыртканда да, торбаларны кул белән борасы түгел – сүс арканнар.* Ш.Мотыйгуллин

5) Конуссыман таякчык рәвешендәге дару препараты. *Геморроидаль шәмнәр*

6) *күч.* Яктылык, нур. *Җырлар минем тормышыма ямь бирделәр. Караңгыда кулларыма шәм бирделәр.* Ә.Ерикәй

◊ **Шәме сүнү** 1) Көчле хис, дәрт сүрелү. *Бер өрүдә зур сөюнең Шәмнәре сүнә микән?* М.Шиһапов; 2) Матурлык, хозурлык тоймый башлау, ямь кимү. *Хуҗа да җырчыга кушылды: Тормыш бит ул, бер карасаң, елмаеп көлгән кебек, Икенче яктан карасаң, шәмнәре сүнгән кебек.* Р.Сәгъди. **Шәм кебек** 1) Туп-туры, төз. *Гөжләп торган ике пилораманың берсе астында кабыгы юнылган гаять юан озын нарат; икенчесендә – шәм кебек төз, нәфис каен агачы...* М.Хәсәнов. *Элекке авыл чыклы иде, гөлле, чирәмле иде... Шәм кебек манаралары үзенчә ямьле иде!* Р.Фәйзуллин. *Сафа Гәрәй хан киң җилкәле, нечкә билле, иярдә шәм кебек төз утыра ---.* Р.Батулла; 2) Төз, зифа буйлы. *Ябыкты хәзер, инде шәм кебек төз, ыспай, биле нечкә аның да, точно синеке кебек.* И.Юзеев. *Син шундый төз, шәм кебек.* Р.Зәйдулла. **Шәм кебек сүнү** *к.* **шәм кебек сызу**. *Айсылуым шәм кебек сүнеп бара бит, көннән-көн ябыга, хәлсезләнә, чүпрәк кебек ап-ак булып калды.* З.Мурсиев. **Шәм кебек сызу** Күзгә күренеп саулыгы китү. *Гөлназ акрынлап шәм кебек сыза, сүнә башлады.* И.Нәбиуллина. **Шәм белән (ягып, тотып, яндырып) эзләсәң дә таба алмау** Бик сирәк табыла, бик сирәк очрый торган әйбер, күренеш турында. --- *әгәр дә тимерче Иван агай китеп барса, ике кулыбызга шәм тотып эзләсәк тә, мондый тимерчене таба алмыйбыз.* Т.Гыйззәт. *Мондый матур, күңелле, иҗади эшне син бит Казанда шәм яндырып эзләсәң дә таба алмыйсың!* А.Хәсәнов

**ШӘМАИЛ** *и. гар.* Изге урыннар, мәчетләр сурәте, гарәп графикасында Коръән аятьләре, догалар, гыйбрәтле сүзләр, шигъри әсәрдән өзекләр һ.б. язылып һәм төрле бизәкләр белән нәкышьләп, рамга куеп стенага эленә торган язма. *Стеналарында бармак калынлыгы кыйммәтле көзгеләр, кара пыялага алтын белән искиткеч матур итеп язылган шәмаилләр, ефәккә чигелгән Мәккә-Мәдинә сурәте.* Г.Бәширов. *Стенада, ишек өстендә – алтын язулы шәмаилләр.* М.Хәсәнов

**ШӘМАИЛЧЕ** *и.* Шәмаил ясау остасы. *Без Нәҗип Нәккашны бәһа биреп бетергесез шәмаилче дип беләбез.* Г.Гомәр. *Безнең газета форматыннан гына да кемнәр генә үтмәгән: чүлмәкчеләр, курчак ясаучылар, сәйлән белән чигүчеләр, күнчеләр, агач эшенә махирлар, шәмаилчеләр...* Шәһри Казан

**ШӘМӘХӘ** *с. гар.* Миләүшә төсендәге, сирень чәчәге төсеннән бераз куерак, кызгылт зәңгәр; *русчасы:* **фиолетовый**. *Мәтрүшкә чәчәге шәмәхә төсле була.* Т.Миңнуллин. *Ал, кызыл, зәңгәр, яшел, шәмәхә җепләр белән бәләкәй сандыкны шыплап тутырып куяр идем.* М.Маликова

**ШӘМӘХӘЛӘНҮ** *ф.* Шәмәхә төскә керү; шәмәхә булып күренү. --- *күз чәчкән кишәрлекләрдә беренче шытымнар борын төртте, андый җирләр ерактан шәмәхәләнеп күренде.* Ф.Садриев. *Күзгә күренеп ак кар зәңгәрләнә, күк белән офык тоташа, бөтен дөнья бер серле төскә керә, ул төс, әле шәмәхәләнеп, әле күкселләнеп, әкертен генә караңгылыкта эри.* Р.Фәйзуллин

**Шәмәхәләнә бару** Торган саен һаман шәмәхәләнү. *Шәмәхәләнә барган тәпәч борын беренче булып штангага Маратны чыгарды.* Д.Гыйсметдин

**Шәмәхәләнә башлау** Шәмәхәләнергә тотыну. *Утәгәнов шәмәхәләнә башлаган зур борынын учы белән уа да уа иде.* Х.Камалов

**Шәмәхәләнә төшү** Тагын да ныграк шәмәхәләнү; бераз шәмәхәләнү. *Эре-эре шомыртлар нык пешүдән шәмәхәләнә төшкән, тик тәлгәшләре пәрәвез белән капланган.* Н.Әхмәдиев

**Шәмәхәләнеп бетү** Тәмам, тулысынча шәмәхәләнү. *Фәез алкаш хатынга җирәнеп һәм аптырап карап торды. Хатынның бите сыдырылып, күз төпләре шәмәхәләнеп беткән --- иде.* З.Хәким

**Шәмәхәләнеп калу** Ниндидер сәбәптән соң яки вакыт узгач шәмәхәләнгән хәлгә килү. *Икесе дә шәмәхәләнеп калган төнге күк йөзенә текәлделәр.* Ф.Яхин

**Шәмәхәләнеп китү** Кинәт кенә шәмәхәләнү. *– Соңгы чара – ампутация. Я аяк, я гомер, хәл шулайрак шикелле? – дип сорады Ваһапов, тән температурасыннан шәмәхәләнеп киткән иреннәрен көчкә кыймылдатып.* Х.Камалов. *Шәмсүн җавап бирмәде, бары кызгылт чырае шәмәхәләнеп киткәндәй булды.* А.Вергазов

**Шәмәхәләнеп тору** Шәмәхәләнгән хәлдә булу. *Шул зәһәрлегеннән кузна борынының яфраклары шәмәхәләнеп тора.* Х.Камалов. *Мин аның шәмәхәләнеп торган зур күзләрендә үземнең кечтек кенә сурәтемне, шәһәр йортларын, машиналарны күрдем.* Г.Сабитов

**Шәмәхәләнеп чыгу** Бөтенләй, бөтен җире шәмәхәләнү, шәмәхә төскә керү. *Комендантның йөзе шәмәхәләнеп чыкты.* Ф.Бәйрәмова. *Ройка --- зал уртасында ап-ак кәфенлеккә төренеп, тын гына ята иде. Битендәге кастет эзләре шәмәхәләнеп чыккан.* Р.Мөхәммәтша

**ШӘМДӘЛ** *и. фар.* 1) Шәм (*1 мәгъ.*) утырту өчен махсус аслык. *Кияү керәсе кичне ул бүлмәне бик нәфис итеп җыялар, һәрбер өстәлгә көмеш шәмдәлләр белән икешәр шәм яндырып куялар ---.* К.Насыйри. *Шәмдәлләрдәге утлар бер янды, бер сүнде, --- күңел болгаткыч төче ис таралды.* Ф.Бәйрәмова

2) *тех.* Шәм (*3 мәгъ.*) урнаштырылган җайланма. *Торба-шәмнәр ничектер бер-берсенә катырак бәрелә, чыңлабрак бәрелә, шәмдәлдән кисәгрәк куба иде.* Г.Ахунов

**ШӘМРӘЙТҮ** *ф. диал. к.* **шомрайту**. *Бара торгач, атым кинәт бөтен гәүдәсе белән куырылып куйды да, колакларын шәмрәйтеп, баскан урынында катып калды.* Г.Бәширов. *Яшь айгыр, сискәнеп, колакларын шәмрәйтте.* М.Шаһимәрдән

**ШӘМ-ЧЫРАК** *и. иск. шигъ.* Яктылык символы, нур, маяк. *Гарипләр шәм-чырак күргәндә юлда, Дисеннәр: бер заман бар булган ул да.* Дәрдемәнд

**ШӘҢГӘ** *и. фар.* Түгәрәкләп җәйгән камыр өстенә изгән бәрәңге, эремчек, җиләкләр һ.б.ш. ягып пешерелә торган ашамлык. *Шәңгә, бәтерләрне әйткән дә юк, авыл җиңгиләренең сылда, ягъни колмактан ясалган баш белән әчетелгән икмәкләренең аклыгы һәм хуш исе ел буена такы-токы яшәгән студент халкының һушын ала ---.* Н.Әхмәдиев. *Өстәлгә бер-бер артлы, борыннарны кытыклап, майда изеп пешерел-*

*гән бәрәңге шәңгәсе, ачы коймак, сөтле аш килеп утыра.* И.Диндаров

**ШӘП-** *кис.* [ш] авазына башланган «шәрә» сыйфатына ялганып, шуның артыклык дәрәҗәсен ясый торган алкисәкчә. *Яр буе шап-шәрә, ап-ачык иде.* Н.Фәттах. --- *безнең хөрмәтле Александр Иванычыбыз бер куак төбенә чүмәшкән дә шәп-шәрә килеш утырыпмы-утыра.* Г.Кашапов

**ШӘП** *рәв. гар.* **1.** 1) Яхшы, әйбәт, менә дигән итеп, җиренә җиткереп, тиешле дәрәҗәдә. *Немецча бик шәп белә, чит телләр факультетында укый.* Л.Ихсанова. *Беркөнне, иртән сабанга киткәндә, хатынына шәп итеп мунча ягарга --- кушты.* Ә.Баян

2) Көчле, интенсив рәвештә. *Коры каен шәп яна ---.* Р.Вәлиев. *Кичә яңгыр шәп яуды шул, аяк асты бик юеш.* Г.Якупова

3) Тиз-тиз, зур тизлек белән, кызу, җәһәт. *Без менә шул авылга шәп кенә юырттырып, дәртле кыңгырау тавышы белән сәламләп килеп кердек.* Ә.Еники. *Карурманнар, агымсулар һаман саен артта кала, ди. Үзенең шулай шәп баруына сөенеп җырлап та җибәргәли икән.* Ф.Яруллин

**2.** *с. мәгъ.* 1) Уңай әхлакый сыйфатларга ия булган, яхшы холыклы, әдәпле, итагатьле. *Була кияүләр – урта куллы гына бер егет – әллә ниткән шәп кешенең бер дә хикмәт шәп кызын ала да гомере буе шул шәп кешеләрне санга сукмый, җаннарын ашый, кызларын каһәрли.* М.Мәһдиев. *Шәп егетләр сез, ләкин хатын-кыз мәсьәләсендә бер тиенгә дә ярамыйсыз, диде Рөсти, Низамның йомшак ягына кагылып.* Г.Рәхим // Әйбәт, яхшы, матур, чибәр, күркәм. *Яшь чакта танцыдамы, кайда берәр матур кыз күренсә: «Шәп кызлар бар иде», – дия торган идек.* Н.Нәҗми

2) Сыйфатлы, тиешле таләпләргә җавап бирә торган; яхшы, әйбәт. *Квартирасы бик шәп һәм иркен икән.* М.Әмир. *– Мин өмәләрне бик тә яратам, – дип дәвам итте «ялкау егет», – минем хәтта өмәгә багышлап чыгарган бер шәп җырым да бар ---.* Х.Ибраһим

3) Чагылыш дәрәҗәсе зур булган, көчле, интенсив. *Төзелеш патроны да шәп тавыш чыгара.* Шәһри Казан

4) Эре. *Шәп адым белән килде дә кинәт туктап калды*

**ШӘПКӘ** *бәйл.* 1) Нәрсә дә булса башкарган вакытта, шуның белән беррәттән. *Йөгереп килгән шәпкә тепло-ходның койрык ягына башта сумкамны ыргыттым ---.* С.Сабиров. *Гөлсемнең ят тавышыннан ат, юырткан шәпкә туарылып, арыш басуына кереп китте.* Ә.Галиева

2) Нинди дә булса бер эш башкарылгач та, шунда ук. *Килгән шәпкә авыру янына узды, исәнләште, тамыр тибешен тикшерде ---.* Г.Әпсәләмов. *Басыйр Бариевич, кыюланып, кергән шәпкә планнарын сөйләп бирде ---.* А.Гыйләҗев. *Зуфирә йөгереп менгән шәпкә аның яныннан узып китте, аннары туктап, аска карады ---.* М.Маликова

**ШӘПЛӘНҮ** *ф.* 1) Тәкәбберләнү, үзен башкалардан өстен кую, эре кылану, эреләнү, һавалану; мактану. *– Курыкма син аңардан. – Мин курыкмыйм да, – дип шәпләнде яшь солдат.* И.Хуҗин. *Киемеңне үзең юып, ашарга үзең пешереп, савыт-сабаңны үзең җыештыра башласаң, бик шәпләнеп, чәчкә атып йөри алмассың ---!* Д.Булатова

2) Батыраю, гайрәтләнү. *Сезне кичә утырып торды диләр. Алай да артык шәпләнеп китмәгез, өзлегү дигән нәрсә бар бит, ишеткәнегез бармы?* С.Сөләйманова. *– Танытам мин аларга! – дип шәпләнде Шәүкәт. – Минем алда биеп кенә торачаклар, күр дә тор.* К.Кара

3) Күркәмләнү, матурлану. *Гранит --- Кадриянең терсәгенә орынды: – У-у, бүген иртән бигрәкләр дә чибәрләнгән, шәпләнгән син ---.* М.Шаһимәрдәнов

4) Яхшыру, әйбәтләнү. *Барасы юл бик аз гына шәпләнә.* Г.Бәширов. *Йөреп керү икесен дә айныткан, бигрәк тә директор шәпләнгән, аның кәефе күтәрелгән, ачуы чыгып беткән иде.* Р.Мирхәйдәров // Терелү, уңайлану, савыгу (авыру кеше тур.). *Мин яңа гаскәрдән кайттым. Шәпләндем, тазардым.* Һ.Такташ

5) *куч.* Артык оста сөйли башлау; телләшергә остару. *Аннары ул, миңа карап: – Җиңгәң телгә-тешкә бик шәпләнде әле, Сирин, нишләргә? – дип көлде.* Х.Сарьян

**Шәпләнә бару** Торган саен ныграк шәпләнү. *Хәлегез шәпләнә бара. Шаярта, төрттерә, хәтта чәнчә башладыгыз.* Т.Галиуллин

**Шәпләнеп китү** Билгеле бер моменттан, сәбәптән соң шәпләнү, кинәт шәпләнү. *Әмма көннәрнең шулай тоташ шәпләнеп китүе, килгән кунакларның юмартлыгы --- хатынымның күңелен дә йомшартты ---.* А.Гыйләҗев. *Шуның аркасында кәефе дә шәпләнеп китте.* Ф.Яхин

**ШӘПЛӘП** *рәв.* 1) Тиешле дәрәҗәдә, җиренә җиткереп, менә дигән итеп; яхшылап. *Аның бу хәлен начальник үзенчә аңлады: – Син кайгырма, Сафина, алдагы елда беренче чиратта сиңа бирербез, – дип юатырга тырышты. – Ә бу бүлмәне бик шәпләп эшләп чык инде.* Г.Сабитов. *Назыйм да яңа урамда бик шәпләп яңа өй салып куйды.* Ф.Яруллин // Яхшы итеп, шәп итеп. *Иван Ивановичның ата-анасы исән, үзе Басыйр Бариевичка сөйләгәнчә, хәзерендә чик янындагы шәһәрчектә бик шәпләп яшәп яталар.* А.Гыйләҗев. *Бер кызы белән кияве шушы авылда ресторан тота икән, без шунда бик шәпләп кунак булдык.* Р.Батулла // Яхшылап, ныгытып, әйбәтләп. *Кечкенә тәрәзә эчтән бик шәпләп томаланган.* М.Хәсәнов. *Ә без элек картлар буганча итереп будык буаны. Машина-машина чыбык-чабык салдык, шәпләп таптаттык, тыгызлаттык.* М.Вәлиев

2) Тәкәббер генә, эре кыяфәттә. *Ибрай белән Хөсәен шәпләп үтеп баралар.* М.Фәйзи

**ШӘПЛЕК** *и.* 1) Шәп булу, яхшы, әйбәт булу. *Кыскасы, солдатмы, офицермы – аерып булырлык түгел, бары тик кыяфәтенә, тотышына, өс-башының шәплегенә карап кына чамаларга була.* Ф.Әмирхан. *Киерелеп шулай сәхнәдә йөргәндә, минем шәплекне барысы да күрәләрме икән, дип аска – залга күз салуым булды – әйтәсе сүзне онытттым.* М.Мәһдиев

2) Көч дәрәҗәсе, интенсивлык. *Хәзер тавышлар сирәгәйгән, элекке шәплекләрен югалткан иде.* М.Гафури. *Җилнең катылыгына, буранның шәплегенә карамыйча, Нурый картның ишегалдын, капка төбен халык сырган иде.* Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар

3) Булдыклылык; кәттәлек; егетлек. *Менә бит, ул остазы белән карулашуны шәплек саный...* Г.Ибраһимов. *Кая китте синең элекке шәплегең?* Ә.Исхак

4) Тизлек, җәһәтлек. *Поезд берничә көн буенча шул шәплеге белән алга китте.* М.Гафури

**ШӘ́П-ШӘП** *рәв.* **1.** Бик тиз, кызу итеп, җәһәт кенә. *Ул шәп-шәп атлап чыгып китте дә директорны алып керде.* Ф.Яруллин

**2.** *с. мәгъ.* Киң, озын, эре. *Карлыгач сүзләрнең мәгънәсен төшенеп өлгермәде, урман каравылчысы атыннан*

*сикереп төште, шәп-шәп адымнар белән аның янына килде ---.* Ә.Хәлим

**ШӘР** *и. гар. иск.* Явызлык, яманлык. *Кан эчүче бүреләрнең шәрләреннән Якын булды котылырга куй һәм сарык.* М.Гафури. *Шундый җилкенгән йөрәкле егетләрнең шәреннән мине дә саклаучылар булган булсачы.* М.Фәйзи

**ШӘРАБ** *и. гар.* Йөзем яки җиләк-җимеш суын тулысынча яисә өлешчә әчетеп ясалган исерткеч эчемлек. *Ришат минем янга килгән иде, юк кына бәхәстә җиңелеп, өч шешә йөзем шәрабы оттырды ---.* Ә.Баян. *--- телгә оста Хәмит --- кызны тиз генә өстәл артына утыртты да, минем арзанлы шәрабымны читкәрәк этеп, үзе алып килгән шампан шәрабын ачты.* Х.Ибраһим

**ШӘРАФӘТ** *и. гар. иск. к.* **шәрәфлелек**. *Аңгыра аюдан Уралдагы курыккандай, Әй туганнар, наданлыктан курку кирәк! Илтифат ит: укудадыр шәрафәтләр, Җаһиллектән килә ятыр зур афәтләр.* М.Акмулла

**ШӘРАФӘТЛӘ́Ү** *ф. иск.* Олылау, шәрәф күрсәтү. *Бер җан белән тиздән милләт итә бәйрәм. Шәрафәтләп, туган көнне бу мөхтәрәм.* Г.Тукай

**ШӘРӘ** *с. мар.* **1.** 1) Ялангач, берни дә кимәгән. *Миңа үз гомеремдә бер тапкыр да андый җиргә барырга туры килмәгәнлектән, ресторанны эчү һәм шәрә кызларның өстәл өстенә менеп бию урыны дип күз алдыма китерә идем.* Ф.Яруллин. *Интегә иде Гөлзәйнәп, җаны кыйнала иде аның, чөнки шәрә кешегә карарга ояла, пляжларны «шүрәле оясы» дип атый, шәһәр халкының бу кыланмышын кыргыйлык дип саный иде.* М.Маликова

2) Яфраксыз, яфракларын койган. *Зәп-зәңгәр күк фонында шәрә агачлар башындагы былтырдан калган карга оялары ап-ачык күренәләр.* Г.Әпсәләмов. *Шулчак, юлның сул як кырында үсеп утырган куакларның шәрә ботакларын, --- коелган яфракларын кыштырдатып, нәрсәдер хәрәкәтләнеп алды.* М.Хәсәнов

3) Йонсыз, йоны булмаган яисә йонын койган. *Шәрә тавык кебек калдырдылар Ярымшәрә кала кызлары.* Ч.Мусин. *Икенче кошларның йомыркадан көчсез шәрә кошчыклар чыга.* Ватаным Татарстан

4) Такыр, тип-тигез. *Авылның --- җире-суы да тирә-як авылларныкыннан бернәрсәсе белән аерылмый: үрләр, үзәнлекләр җәелгән шәрә кырлар, чокыр-чакырлар, вак куаклыклар ---.* Ә.Еники. *Тирә-якта ат кылыдай каты, коры үләннәр генә тырпаеп утырган иксез-чиксез далалар, тигез, шәрә далалар башланды.* Н.Фәттах // Берни дә үсмәгән, бернәрсә белән капланмаган. *Түбәләрендә шәрә ташлар тырпаеп утырган, итәкләре исә куе яшел урман белән капланган, бер үк биеклектәге ике калкулыкны шулай Куш тау дип атыйлар иде.* Н.Фәттах. *Шәрә башын иеп, агай якты лампа астында уйланып утыра.* Ш.Галиев

5) Бернинди дә җиһазы булмаган, җиһазланмаган, буш. *Шырпы яктысы чаршау-кашагасыз шәрә өй эчен беркавым үзенең калтыравык нурына манчыган булды да, караңгылыкны җиңә алмаячагына ышанып, сүнәргә ашыкты.* Ә.Гаффар. *Чакырырга кирәк үзләрен, бер килгәч күңел шундый карарга. Шәрә туташ кебек шәрә бүлмәм бик ошарга тиеш аларга...* Р.Мингалим // Берни дә җәелмәгән, түшәлмәгән; коры, как. *Ул блокка керде. Монда да шул ук өч катлы шәрә сәкеләр, тонык кына электр уты, ябык, ач кешеләр.* Г.Әпсәләмов

**2.** *рәв. мәгъ.* Киемсез, ялангач, киемсез килеш, киенмичә. *Нишләсен, ипотекага түләргә, ниһаять, үлмәс өчен генә тәгам кабарга, шәрә йөрмәс өчен генә киенергә мәҗбүр иде рәссам.* Н.Гыйматдинова

**ШӘРӘГӘН** *с. диал.* Чәберчек. *Шәрәгән йомырка*

**ШӘРӘЛӘНДЕРҮ** *ф.* 1) Шәрә итү, каплап торган нәрсәне алу, ачу. *Солдатлар, кылычларын шәрәләндереп, ишекнең ике ягына тезелеп бастылар.* М.Галәү. *Иртәнге җил, аның чигәләре агара төшкән саргылт чәчен бер якка сибеп, баш түбәсендәге пеләшен шәрәләндерде.* А.Вергазов

2) *күч.* Яшерен якларын фаш итү, ачу, ачып салу. *Явызлыкның иҗтимагый тамырларын тәмам шәрәләндереп, ачып салган реализм формалашып өлгерә алмады әле.* Г.Халит. *Көндәлек ул – истәлек тә, тормыш вакыйгаларын шәрәләндереп бирү һәм тарихка әйләнеп баручы вакыйгаларның чагылышы да.* Ф.Яруллин

3) *күч.* Гади итеп, катлауландырмыйча, матурламыйча, яшерергә тырышмыйча ачыктан-ачык бирү. *Профессор борынын җыерып куйды, бу сорау аңа артык тупас тоелды булса кирәк. – Шәрәләндереп әйткәндә, шулайрак шул, – диде ул.* М.Маликова. *Гасырыбызның фаҗигасы сәхнәдән бу дәрәҗәдә шәрәләндереп күрсәтелгәне юк иде әле.* К.Тимбикова

**ШӘРӘЛӘНҮ** *ф.* 1) Шәрә хәлгә килү, ялангач, бернәрсәсез калу. *Йөзәр яшьлек карт тупыллар, кәкре-бөкре булып үскән моңсу каеннар күптән инде шәрәләнгәннәр.* М.Хәсәнов. *Картаеп очлары шәрәләнгән имән ботакларында бала-чага сырышкан булган.* А.Вергазов

2) Бушау, бушап калу; такыраю. *Урамнар шәрәләнде, тузан басты.* Ш.Галиев. *Бу кибеттә күптән булмаган иде, шүрлекләрнең шәрәләнүенә хәйран калды.* М.Хуҗин

**Шәрәләнә бару** Торган саен ныграк шәрәләнү. *Көзнең беренче атналарында алтыннан койган шикелле сары яфраклары белән шыбырдап утырган ак каеннар, кызгылт яфраклы усаклар, өрәңгеләр хәзер көннән-көн шәрәләнә баралар.* Г.Әпсәләмов. *Авыл тирәсендәге әрәмәләр, урманнар хәзер елдан-ел сирәгәя, шәрәләнә бара.* Н.Фәттах

**Шәрәләнә башлау** Шәрәләнергә тотыну. *Уң кулы белән чигә чәчләрен шәрәләнә башлаган баш түбәсенә таба сыпыргалады ---.* Т.Әйди

**Шәрәләнә төшү** Тагын да ныграк шәрәләнү; бераз шәрәләнү. *Тау битләре дә шактый шәрәләнә төшкән, чөнки анда яфраклар иртәрәк коела, үлән иртәрәк корый.* Ф.Бәйрәмова

**Шәрәләнеп бару** Акрынлап шәрәләнү. *Монда хәзер итәк асты да шәрәләнеп бара.* Ф.Яруллин. *Бар табигать шәрәләнеп бара, Басу арты басу карала.* Н.Әхмәдиев

**Шәрәләнеп бетү** Тәмам, тулысынча шәрәләнү. *Калкулыкларның --- түбәсендә җил яңгырдан ергаланып, шәрәләнеп беткән кара ташлы кыялар тырпаеп утыра.* Н.Фәттах. *Су читендә үскән өянкеләр көмеш толымнарын агымсуда чайкый, --- шәрәләнеп беткән тамырлары ярга чат ябышып җирне кочкан.* Х.Мөдәррисова

**Шәрәләнеп калу** Нindидер сәбәптән соң яки вакыт узгач шәрәләнгән хәлгә килү. *Агачлар тәмам шәрәләнеп калды, елгалар-күлләр юка гына боз белән капланды, ялан-кырларга ак кырау ятты.* Ә.Еники. *Камил бер ярымүлек кызга, бер миңгерәйгән малайларга, бер бушап, шәрәләнеп калган бүлмәгә карады.* Ф.Бәйрәмова

**Шәрәләнеп килү** Соңгы вакытта шәрәләнү. *Явыз җил --- шәрәләнеп кил-*

*гән агачларны әле бер, әле икенче якка сыгылдырды, урамдагы тузанны пыр туздырып ташлады.* Г.Хөсәенова

**Шәрәләнеп тору** Әле, хәзер шәрәләнеп күренү; гел, һәрвакыт шәрәләнгән хәлдә булу. *Революция тавындагы туганнар кабере тирәсенә яшь агачлар утырткач, Закир кодасы белән Гөргери карт Абуздырин: – Анда безнең һәйбәтләп рәшәткә тотмыйча ярамый: шәрәләнеп тормасын!* Э.Касыймов. *Сәмигулла агай гарип, сул аягы урынында агач бүкән генә шәрәләнеп тора.* Сөембикә

**ШӘРӘЛӘ́Ү** *ф. к.* **шәрәләндерү**. *– Сез барын да бераз гына матурлыйсыз. – Ә сез, Гәрәй Гыйльманович, артык шәрәлисез.* А.Гыйләҗев. *Язгы ташкын сулар аның тамырын юыпюып шәрәләгәннәр ---.* Я.Зәнкиев

**ШӘРӘЛЕК** *и.* 1) Шәрә булу үзлеге. *Кая гына карама, күз күреме җиткән җирдә ялангач кызыл балчыклы ямьсез таулар да сыртлар, үрләр дә түбәләр. --- Бөтен тирәдә шәрәлек-шыксызлык.* Ш.Маннур. *Өй кызу булгангамы, өстенә япкан җәймәсе шуып төшкән. Үзе йоклый, шәрәлеген дә, Җәмилнең күз карашын да сизмичә йоклый.* Н.Әхмәдиев

2) **шәрәлекләр** *күпл. геогр.* Шәрә тау башларыннан гыйбарәт урын, ялантау; *русчасы*: **голяки**

**ШӘРӘФ** *и. гар.* 1) Мактаулы эш, горурланырлык нәрсә, дан. *Бердәнбер углын югалту нинди авыр хәсрәт аңа. Шулай да халык өчен шат йөз белән үлемне каршы алу – улы өчен зур шәрәф – хурлыкта китмәде дөньядан бала.* Г.Камал. *Мин – татар артистлары арасында совет шартларында беренче булып азмы-күпме булса да театр мәктәбендә тәрбия алу шәрәфенә ирешкән артистларның берсе.* Т.Гыйззәт

2) Шәхеснең абруе, кешелек дәрәҗәсе, авторитет, престиж. *Кунаклар телләрен тешләделәр, алар, үзләренең шәрәфен саклау белән бергә, гауга чыгармыйча бетерү ягындалар иде.* Г.Ибраһимов

3) Кешегә күрсәтелгән илтифатлы мөнәсәбәт, кадер, хөрмәт. *Хатын-кызның адәмлек шәрәфен (кадер-хөрмәтен, затлылыгын) кимсетә торган вәхшилек законнар бетерелсен.* Т.Биктимирова

4) Берәүнең икенче затка карата кылган, горурлык, канәгатьлек, бәхет итеп бәяләнерлек эш-гамәле. *Син мәсгудьсең, чөнки фидаилек шәрәфенә ирешкәнсең; яки халык өчен утыз еллап зинданда ятып, сакалың агаргач чыгарылып, халык тарафыннан зур ихтирам илә каршы алынасың.* Г.Ибраһимов

**ШӘРӘФӘ** *и. гар.* Мәчет манарасындагы балкон. *Сүзлектә Казандагы яңа Мәдинә мәчетенең манарасы ике балконлы диелгән. Балконың балкон инде, ләкин ул шәрәфә --- дип атала бит.* А.Тимергалин. *Шәрәфәдән азан әйтү*

**ШӘРӘФЕНӘ** *бәйл.* Хөрмәтенә. *Университетны тәмам итеп чыгучылар шәрәфенә банкет-мәҗлес ясалды.* Г.Кутуй. *Кардәш-ыру, зат-кавемнәрегезгә, барлык әрвахлар шәрәфенә багышланган догам булсын берук!* М.Хәсәнов

**ШӘРӘФЛӘНДЕРҮ** *ф.* Хөрмәт күрсәтү, олылау. *Аллаһы Тәгалә бу бәндәсенең күңеленә тәүфикъ вә һидаять салып, иман белән шәрәфләндерде.* Гасырлар авазы

**ШӘРӘФЛӘНҮ** *ф.* Шәрәф казану, дәрәҗәсе арту. *Җирле халык ислам нуры белән нурланган, шәрәфләнгән.* Безнең мирас

**ШӘРӘФЛЕ** *с.* 1) Мактаулы, хөрмәтле, почётлы; дәрәҗәле, абруйлы. *Коммунист, депутат, бюро члены, пленум әгъзасы Сабит Йосыф улы Нургалиев тагын бик күп мактаулы, шәрәфле исемнәргә лаек булыр иде ---.* А.Гыйләҗев. *Без анда профессор Абдулла Аббас белән күрештек. Ул – ТР Фәннәр академиясенең шәрәфле академигы да.* Р.Вәлиев

2) Шәрәф бирә торган. *Тантананы ачу – шәрәфле эш*

3) Кадерле, изге саналган, күңелдә сакланган, онытылмаслык. *Добруҗа вә сөекле Ватаныбыз, Булсын шанлы, шәрәфле ятагыбыз!* Т.Әйди. *Урак вакытында тупырдап торган уллары туды. «Шәп вакытта, шәрәфле айда, урак өстендә туды, Шәрәфетдин кушабыз», – диде Аяз хәзрәт.* Р.Сибат

**ШӘРӘФЛЕЛЕК** *и.* Хөрмәткә, ихтирамга лаек булу, олы дәрәҗәлелек

**ШӘРӘФСЕЗ** *с.* Абруйсыз, дәрәҗәсез; хөрмәтен саклый алмаган. *Ул заман бу шаулаган шанлы шәһәрләр кечкенә Бер фәкыйрь, рухсыз авыл булган, шәрәфсез мескинә.* Дастан

**ШӘРӘФСЕЗЛЕК** *и.* Шәрәфе булмау; хөрмәт ителмәү күренеше

**ШӘРГЫЙ** *с. гар.* 1) Шәригать белән бәйле булган, шәригать мәсьәләләренә караган. *Мөселманнар өчен махсус шәргый журнал темасы татар матбугатында тотрыклы урын яулый.* Р.Фәхретдин. *Бусы, хәзрәтлеген яшереп, тамак өчен Бик зур шәргый хәйлә ясаган.* Һ.Такташ. *Мөҗтәһидләр шулар нигезендә шәргый хөкемнәрен чыгара алалар.* А.Тимергалин

2) Шәригатьчә булган; шәригатькә туры килгән, шәригатьне бозмаган, законлы. *Ислам кануннары буенча, мондый шартнамә аларны шәргый ирлехатынлы пар дип раслап куя.* Г.Исхакый

**ШӘРЕХ** *и. гар.* 1) Берәр текстның, китапның кыен, аңлашылмаган урыннарына карата язылган аңлатма, өстәмә мәгълүмат, комментарий, искәрмә. *«Фатиха» сүрәсенең шәрехе*

2) Берәр китапны ачыклау, аңлату өчен язылган әсәр. *Мәдрәсәләрдә ул китапның үзен түгел, ә шул әсәргә шәрех китапларын өйрәнгәннәр.* Г.Исхакый

3) Гомумән аңлатма, ачыклама. *Гордеев та, Кутузов та икесе бер сүздә торалар: имеш, «казак» сүзе ул иректе, азат кеше дигән сүз, дип әйтәләр. Әйе, алай да шәрехләп була. Ләкин бу шәрех ярым-йорты гына булып кала.* Р.Батулла

**ШӘРЕ́Х ИТҮ** *ф. к.* **шәрехләү**. *Падишаһымның дәхи кырык вәзире, мәгърифәтле вә дана адәмнәр – һәрберсе хәзергә падишаһымызга сәер күренгән сүзләр шәрех итәрләр.* К.Насыйри

**ШӘРЕХЛӘНҮ** *ф. төш. юн. к.* **шәрехләү**. *Ике кеше арасындагы мөнәсәбәтләр булудан бигрәк, мәхәббәт хисе кеше күңеленең чистару, бөеккә һәм биеккә ашкыну халәте кебек шәрехләнә.* Г.Ибраһимов. *Габделнур да, бүтән малайлар-кызлар да радиодан шәрехләнгән сүзләрнең күбесен аңламыйлар иде, әлбәттә.* Р.Кәрами

**ШӘРЕХЛӘ́Ү** *ф.* 1) Нәрсәгә дә булса аңлатмалар, комментарийлар бирү. *«Татарның әхлакый кодексы»н шәрехләгәндә, минем өчен иң авыры шушы пункт булгандыр.* Т.Миңнуллин

2) Аңлату, аңлатып бирү, нәрсәне дә булса төшендерү, төшенергә ярдәм итү. *Әйтерсең шагыйрь бу шаян да, моңсу да шигырен төрмә камерасында түгел, ә агым су буенда берьялгызы моңланып йөргәндә язган. Моны шәрехләп, дөрес сыман тоелган әллә ничә төрле аңлатма табарга мөмкин ---.* Г.Әпсәләмов. *Бик хуш, камалышта калган шәһәр кешеләре үргән бодай ашап кына ач үлемнән котылып калганнар, дип шәрехләде әлеге йоланы Мөхәммәдәмин.* М.Әмирханов

**Шәрехләп китү** *к.* **шәрехләп үтү**. *Мин бары тик барыбызга да – үземә дә, сезгә дә кайбер сораулар гына куймакчы булам. Һәм киләчәктә ниләр эшләп була икәнен шәрехләп китәргә уйлыйм.*

Р.Миңнуллин. *Адвокат сезнең дәгъвагыз асылын кыскача гына шәрехләп китте.* Ә.Сафиуллин

**Шәрехләп тору** Һәрдаим, әледәнәле шәрехләү; хәзерге вакытта шәрехләү. *«Мигрантлар --- табигатьне чүп түгә торган чокыр хәленә китереп калдыралар». Мондагы, бу өзектәге тирән мәгънәне шәрехләп торуның кирәге юк кебек.* М.Мәһдиев

**Шәрехләп узу** *к.* **шәрехләп үтү**. *Ул «ЛУКОЙЛ»ның Зөядәге мәдәни һәм тарихи мирас һәйкәлләрен торгызу һәм яңартуда да актив катнашуын шәрехләп узды.* Г.Гарифуллина. *Р.Миңнеханов Илбашы Путинның Татарстан җитәкчесе атамасы турындагы сорауга җавабын шәрехләп узды*. Мәйдан

**Шәрехләп үтү** Сүз уңаеннан шәрехләү. *Бераз кызык булсын әле, дип, Әлфия апа белән сөйләшүемне аңа да шәрехләп үттем.* Ф.Баттал. *Шуңа бәйләп, югарыдагы фикернең капма-каршысын, ягъни татарларның борынгы бабаларының Идел буенда бик борынгыдан яшәвен раслаучы икенче бер карашны шәрехләп үтәсе килә.* Ф.Хисамова

**Шәрехләп чыгу** Башыннан ахырына кадәр эзлекле шәрехләү. *Ислам туган, Сезнең тормыш юлыгызны мин кыскача гына шәрехләп чыктым инде.* Р.Вәлиев. *Татар шәмаиле галереясы арт-директоры, сәнгать фәннәре кандидаты Рөстәм Шәмсутов һәр эшкә үз бәясен биреп шәрехләп чыкты.* Шәһри Казан

**ШӘРЕХЧЕ** *и.* Аңлатма бирүче, ачыклаучы, шәрехләүче, комментатор. *Француз язучысы Альбер Камю гомер тәҗрибәсеннән чыгып әйткәнчә, «Анык кимәлдә язган каләмнең ишле укучылары, томанлы итеп язганнарның үз шәрехчеләре була».* З.Мансуров

**ШӘРИГАТЬ** *и. гар. дини* 1) Мөселманнар өчен үтәү мәҗбүри булган, Коръәнгә һәм сөннәткә нигезләнеп яки иҗтиһад ярдәмендә билгеләнгән иман, әхлак, гыйбадәт һәм хокук белән бәйле кагыйдәләр һәм хөкемнәрнең бөтенесе, шуларның җыелмасы. *Шәригать рамазан аенда 30 көн ураза тотарга куша.* Г.Исхакый. *Чисталык, пөхтәлек безнең халыкның борын-борыннан шәригать кануннары белән канына сеңгән.* Ф.Яруллин. *Күрәбез: шәригать кушканны сукырларча башкару гына шәхесне иманлы итми икән әле.* Р.Сафин

2) Гомумән һәркем үтәргә тиеш булган кагыйдә, канун, низам. *Муса галәйһиссәлам шәригате*

3) Суфичылыкта: Аллаһка ирешү юлындагы дүрт мәкамнан беренчесе (калганнары – *тарикать, хакыйкать, мәгърифәт*)

**ШӘРИГА́ТЬЧӘ** *рәв.* **1.** Шәригать кануннарына нигезләнеп, шәригать кушканча. *Моннан соң мулла кызның атасын яки вәлиен чакырып сорый: аның кызы ничә яшьтә, ни исемле, мәһәр күпме, кызы ризамы, һәм шәригатьчә шулай кирәк.* К.Насыйри. *Коръәнне яттан белүче зур гыйлем ияләре шушы шартларда да яшереп намаз укыйлар, ураза тоталар, шәригатьчә яшәргә тырышалар.* Ф.Бәйрәмова

**2.** *с. мәгъ. к.* **шәргый**. *Мин бит сине шәригатьчә хатыным бул, дим.* М.Фәйзи

**ШӘРИК** *и. гар.* 1) Нинди дә булса бер эшне, шөгыльне бергәләп алып баручы, компаньон; бергә эшләүче, иптәш. *Шәрәфетдин абзыйның өендә --- зур голәма җәмгыяте булды. Беләсең инде: һәркем үз тиңе вә үз шәриге берлән азаплана бит.* Г.Тукай. *Бу йортларны рәһенгә салып акча табу мөмкин исә дә, аңарга шәрикләреннән ризалык алырга кирәк булачак*. Г.Камал

2) Бер сыйныфта укучыларның һәрберсе (бер-берсенә карата); сыйныфташ, классташ. *Кичке чәйдән соң шәрикләребез дәресханәдә дәрес хәзерлиләр, без исә, укылган әдәби әсәрләр турында сөйләшеп, коридорда йөреп гомер үткәрә идек.* Х.Туфан. *Бәдретдин, безне кыстап: – Ягез әле, шәрикләр, ни бары белән ашап кына эчегез, ашап кына! – диде.* Ә.Еники

**ШӘРИКТӘШ** *и. ялг. к.* **шәрик** (*2 мәгъ.*). *Гармунда үзе уйнап, үзе җырлап, сикереп чыгып биюне дә абруйны төшерүгә санамаган Азат үзенең һәм шәриктәшләренең күңелен күргән мәлдә, мин шыпырт кына мәктәп китапханәсенә юл алдым.* Т.Галиуллин

**ШӘРИФ** *с. гар. кит.* Аерылмыштан соң килеп, «шәрәфле, газиз, кадерле, хөрмәтле, мөбарәк» мәгънәсен белдерә. *Аның җеназа шәрифләрендә 50 мең кеше катнашкан, каберенә зиярәт кылырга килүчеләр 20 көн буена өзелмәгән, дип сөйлиләр.* А.Тимергалин. *Э-эй, Афанасий Фёдорович, безгә әче бал эчәргә ярамый, Коръән шәрифләре рөхсәт итми.* А.Гадел

**ШӘРКЫЙ** *с. гар. кит.* Көнчыгыштагы, көнчыгышка караган, шәрыкка мөнәсәбәтле. *Гомумән, Г. Гобәйдуллинның тирән белемле булуы тәнкыйть мәкаләләрендә әсәрләрне шәркый һәм гарби фәлсәфә, әдәбият фонында карарга мөмкинлек бирә.* Д.Заһидуллина. *Әсәрнең композициясе бик отышлы: Шәркый Төркестанда туган Иркен ага Казанга килеп төшә һәм татар яшәгән төбәкләрдә йөри.* Р.Зәйдулла

**ШӘРКЫЯТ** *и. гар.* Көнчыгыш халыкларының телләрен, тарихын, әдәбиятын өйрәнә торган фән тармагы, ориенталистика. *Шәркыят фәнендә XIX гасыр Ислам реформациясенә нигез салучылар итеп озак еллар мисырлы Җамалетдин Әфгани белән Мөхәммәд Габдеһне атап килделәр.* М.Хәсәнов. *Бүген без Ә.Халидине киң колачлы, тирән белемле шәркыят белгече буларак беләбез.* Г.Госман

**ШӘРКЫЯТЧЫ** *и.* Көнчыгышны өйрәнүче галим, ориенталист. *Әкиятнең исеме дә, канатлы әйтелмәгә әйләнеп, дөньяның бик күп телләрендә кулланыла. Европада ул танылган шәркыятчы Антуан Галлан тәрҗемәсендә тарала башлый.* Х.Мәхмүтов

**ШӘРРА́Н ЯРУ** *ф.* 1) Кычкыру, барысына да ишеттереп җырлау, үкерү һ.б.ш. *Кәефләр бик тә хушланып киткәч, битләр пәрәмәчләнеп, дөньялар тигезләнеп алгач, Николай Иванович шәрран ярып җыр башлады ---.* М.Мәһдиев. *Кайсыныңдыр, мич артында утырган ана казның чыкканын көтеп ала алмыйча, ата казы шәрран яра.* Х.Камалов

2) Берни дә яшермичә, ачыктан-ачык сөйләп бирү. *Ә «олы абзыйлар», гадәтләре буенча, бала-чага кебек шәрран ярып, ду кубып сикереп чыгарга бер дә ашыкмадылар.* Г.Мөхәммәтшин

**ШӘРҮ** *ф. диал.* Озак яту аркасында бозылу, чәберчекләнү. *Беләсеңме, мондый музикан [гармонь] күпме тора? Моңа җыя-җыя җыйган йомыркаларың шәреп бетәр.* Н.Исәнбәт

**ШӘРЫК** *и. гар.* 1) Көнчыгыш, мәшрикъ. *Сез шәрык хикәяләрендә очрый торган пәри падишаһларының могҗизалы гүзәл кызларыннан да матур.* Ф.Әмирхан. *Шәрык биюе биилəр.* Т.Миңнуллин

2) Көнчыгыш халкы, Азия халкы һәм илләре. *Тик соңгы сүзләре генә килеп җитте безгә: – Шәрык уянды! Богаулар өзелде! Гасырлар буенча изелгән мәзлум милләтләргә тулы азатлык килде.* Ә.Еники. *--- ерак Төркестан сахраларында Мулланурны Шәрыкны уятачак нур итеп кабул иткәннәр икән!* Безнең мирас

**ШӘРЫКЛЫ** *с. иск.* 1) Шәрыкка (*2 мәгъ.*) караган, чыгышы белән шә-

рыктан (*2 мәгъ.*) булган. *Гәрчә Фатыйма шәрыклы бер хан кызы булса да, байтак нәрсәләр укып фикере нурланган сәбәпле, хөррият тарафында иде.* Ш.Мөхәммәдев

2) Шәрыкта туып үскән яки шунда яшәүче кеше. *Шәрыклылар иң заманча чит ил техникаларын кулланалар*

**ШӘРЫКЛЫК** *и.* 1) Шәрыклы булу үзлеге. *Күренекле галим Җамал Вәлиди: «Гаязның язганнарын халык аңлый икән, моннан бер дә аның шәрыклыгы чыкмый. Шәрыкның табигате, билгакес (киресенчә), сүзне зиннәтләп, читләтеп, аңлашылмаслык итеп сөйләүдәдер», – дип әйткән.* Р.Рахман

2) Шәрыклыларга хас булган нинди дә булса сыйфат яисә сыйфатлар. *Аның картиналары да ничектер күңелгә үтә дә якын. Аларда төркилек тә, мөселманлык та, шәрыклык та ярылып ята.* Р.Миңнуллин

**ШӘРЫКЧЫЛЫК** *и.* Шәрыкка (*2 мәгъ.*), Көнчыгышка иярү. *Бу беренче дәвер музыка үсешебез дә менә шул милләтче шәрыкчылык идеологиясе йогынтысында булды.* М.Җәлил. --- *татар әдәбияты тарихы ике зур этапка бүленә: 1. Шәрыкчылык дәвере. 2. Аурупачылык дәвере.* Ә.Закирҗанов

**ШӘТ** *мод. сүз сөйл. к.* **шаять**. *Якын атналарда, шәт, ул сугыш туктар яисә зур сугышка әйләнеп китәр.* Г.Бәширов. *Шәт, чанагыздан тибеп төшереп калдырмас идегез әле.* А.Хәсәнов

**ШӘҮВӘЛ** *и. гар.* Ай елының рамазаннан соң килә торган унынчы ае. *Шәүвәл аеның беренче көнендә Алып Бәргән дүртенче тапкыр сөекле әнкәсен, мәгъшукасы Нәүмизәне калдырып, Юханы эзләп, ерак юлга чыгып китте.* Р.Батулла. *Шәүвәлнең егерме икесендә җепшек кар явып үтте.* М.Әмирханов

**ШӘҮКӘТ** *и. гар. кит.* Бөеклек, олылык, һәйбәт; көч, куәт. *Җиһанны тетрәтмеш иде синең олуг шәүкәтең, Кая милкең, кайда гыйльмең, кайда бөек дәүләтең?..* Дастан. *Рус халкы, янәсе, электәге бөеклеген, шәүкәтен югалткан, башкаларга хезмәт итүче, нужа чигүче абруйсыз бер халыкка әйләнеп калган.* Ә.Еники

**ШӘҮКӘТЛЕ** *с. кит.* Шәүкәт иясе, бөек, куәтле, газамәтле. *Хәзер шигырь мәйданында иң шәүкәтле һәм галибәле рольне мөхтәрәм Тукаев уйный.* Г.Исхакый. *Ханыңны, барча гаскәреңне Дошман узып китте... Куәтле, шәүкәтле чакларың кайларга китте?* Ф.Бәйрәмова // Шәүкәт һәм куәтне белдергән, шуны чагылдырган. *Шәүкәтле, мәсхәрәле көлүләр уртасында пәрдә төшә.* Һ.Такташ

**ШӘҮКЪ** *и. гар. иск. кит.* Дәрт, көчле теләк, чамасыз арзу, һәвәс. *Мәхәббәт шәүкы шаһ күңлегә төште ---.* Дастан. *Калмады моннан әсәр, калды мәгәр шәүкың һәнүз.* Г.Тукай

**ШӘҮЛӘ** *и. гар.* 1) Караңгылык эчендә тонык кына булып күренгән якты әйбер, яктылык. *Вәли бай йортындагы кысык ут шәүләсеннән башка авылда бер яктылык та күренми.* Һ.Такташ

2) Берәр нәрсәнең караңгыда, бик еракта яки якты фонда караңгы булып күренгән сызымы, чалымы, силуэты. *Куак арасыннан үрелеп карагач, Наил капчык күтәргән кеше шәүләсен абайлап алды.* К.Кәримов. *Балыкчылар шәүләсен күрәм, тик алар еракта.* Т.Кәримов

3) Нинди дә булса якты әйбердән күк йөзенә төшкән яктылык. *Караңгы күктә янгын шәүләсе уйный, еракта ату тавышлары ишетелә иде.* Г.Әпсәләмов. *Күк читенә зәңгәр төтен җәелгән, һавада ялкын шәүләсе. Авыллар яна ---.* Г.Бакиров // Ялтыравык өслеккә төшкән яктылыктан кире кайткан нур. --- *каршы як стенаның бер почмагында, түшәм янындарак, уч төбе хәтле генә якты тап торып калган, әйтерсең көзге шәүләсе төшкән. Әмма кабинеттагы көзгенең шәүләсе бу урынга төшәрлек түгел иде.* Г.Әпсәләмов. *Сарайларның алтын шәүләләре кешеләрнең күзен тондыра.* Ш.Маннур // Нәрсәдән дә булса чыккан яктылык нуры. *Сопкаларда шәфәкъ шәүләсе.* Г.Сабитов. *Нур шәүләсенең яктысы бүген --- күңелле тыкылдавы белән киң кырларны, урманнарны уятып, еракка ашкынган поездга юнәлгән иде бугай.* М.Маликова

4) Берәр әйбернең икенче бер нәрсәдә чагылышы, чагылган рәсеме. *Ирек күктәге йолдызларга, аларның судагы шәүләләренә хәйран калып карап торды.* Ф.Садриев. *Бервакыт мин күзләремнең көзгедәге шәүләсен генә түгел, ә чын, тере күзләремне күрергә теләдем.* Г.Рәхим. *Мансур Ибраһимович, поездның икеләтелгән тәрәзә пыяласында үз шәүләсен --- күреп, бермәлгә сискәнеп китте.* Х.Ширмән

5) Нәрсәнең дә булса күз алдына килгән, кабат гәүдәләнгән сурәте. *Аның хыялы күкләргә сыя алмыйча тырпылдый, һәм аның күз алдындагы Нәҗип шәүләсен көтмәгәндә Сабит абыйсы алыштыра.* А.Гыйләҗев. *Доктор, бу карчыкны кайда күрдем соң, дип озак уйлап торганның соңында, җимерелгән, кипкән карчыкта ул --- үзе бервакытларны бөтен хәятын фида итәргә йөргән Гөлсемнең шәүләсен күрде.* Г.Шакирова

6) Күләгә. *Ул берчакта да үзе турында авыз ачып сөйләми, ярканат кебек очып кайта, күргәне аның шәүләсен күреп кала, күрмәгәне күрми, берәү дә артыгын төпченми.* А.Гыйләҗев. *Иң үзәккә үткәне: Мөслимә үз шәүләсеннән үзе көнләшүче усал, зәһәр хатынга әверелде.* Н.Әхмәдиев

7) *күч.* Хис, тойгы кебек эчке кичерешләрнең йөздә, чырайда чагылышы. *Аның йөзендә, күз төпләрендә, беренче кырауга эләккән көзге чәчәктәй, бераз шиңә, шәлперәя башлау билгеләре, күзләрендә исә карт кыз булып утырып калудан курку шәүләсе бар иде.* Г.Бәширов. *Кинәт ул, һушына килеп, танымаслык хәлгә җиткән мәеткә карап катып калды. Йөзеннән нindидер шәүлә үтте.* М.Кәбиров

8) *күч.* Тормыш, яшәешне караңгылый торган күренешнең чагылышы, тәэсире, йогынтысы. *Алтын Урдага карата ул галәмкүләм нигезсез, ачулы үчләнүләрнең энергиясе, нәтиҗәләре бүген дә әле халкыбыз язмышында кара шәүләсен саклый.* М.Гайнетдинов. *Гәүдәсенең, тәненең үзенә буйсынмыйча эрүен, сүнүен тойды, офыкта кызыл тамчылардан торган үлем шәүләсен күргәндәй булды.* Т.Галиуллин

9) *күч.* Рух, идея. *Җир шары өстендә Ленин шәүләсе көн-төн йөри.* Һ.Такташ. *Мин генә түгел, барлык шагыйрьләр дә шул хәлдә бит, тик барыбыз да ризалашабыз, шигырьнең шәүләсен генә булса да укучыга, татарча белмәүче укучыга ирештерәсе килә.* К.Тимбикова

10) *күч.* Һәрвакыт үзеңнән калмый, юкка чыкмый торган нәрсә (язмыш, бәхет, бәхетсезлек һ.б.ш. психик хәлләр). *Кая барсаң, анда шәүләң – нужа!* Ш.Маннур

◊ **Шәүлә генә калу** Бик нык ябыгу. *Ул ябыккан, күзләре эчкә баткан. Элеккеге шаян җегеттән карачкы шәүләсе генә калган.* Р.Батулла. *Ниһаять, беркөнне ире кайтып төшә. Типсә тимер өзәрдәй ирнең шәүләсе генә калган.* З.Мәхмүди. **Шәүлә кебек** 1) Гел ияреп, арттан калмыйча. *Инде бу вакыйга онытылган дип уйлаган идем, шәүлә кебек һаман*

*арттан сөйрәлеп килә икән.* Т.Галиуллин. *Ул беренче очраган көннән үк шәүлә кебек ярты тотам да калмыйча, ияреп йөрергә гадәтләнде.* Н.Гыйматдинова; 2) Тавыш-тын чыгармыйча, сиздермичә, шыпырт кына. *Шәүлә кебек тавышсыз, сагышлы моң кебек тын гына йөргән Гордейны Гофман мичләре өстендә, күмер тузанын җил өерләгән чарлакта күз алдына китердем.* А.Гыйләҗев. *Рәсим мич арасыннан шәүлә кебек чыгып китте. Идән буенча барганда да, идән такталарын шыгырдатмады.* Ф.Шәфигуллин. **Шәүлә төшерү** Тап төшерү; кимчелек китерү; күләгәләү, арткы планга этәрү. *Исхакыйны күтәрү Тукай данына шәүлә төшерми икән.* Т.Галиуллин. *Бу хәл образның идеальлегенә нииндидер шәүлә төшерми калмый, әлбәттә.* К.Гыйззәтов

**ШӘҮЛӘЛӘНҮ** *ф.* 1) Күзгә чалыну, беленү, ерактан яки караңгылык эченнән бик аз гына күренә башлау. *Бер адәмнең акрын сүзе колагына чалынды, алда берничә карачкы шәүләләнде, кыз һаман барды.* Г.Ибраһимов. *Офыкта мираж уйный башлый, анда шәһәр, гөлбакчалар шәүләләнә.* Ф.Хатипов

2) Шәүләләр, күләгәләр барлыкка килү; шәүләләр уйнау

3) Бер әйбердән яки яктылыктан икенче бер урында, әйбердә чагылыш барлыкка килү; чагылу. *Таулар, урманнар, күл төбендә шәүләләнеп, әкияти бер күренештә балкыйлар.* И.Салахов

4) Нинди дә булса рухи хәл йөздә, чырайда чагылу, беленү. *Кәбир әфәнденең йөзендә шәүләләнгән болыт тарала, җуела барды, борчылу тынычлануга әверелде, ниһаять, аның йөзендә елмаю пәйда булды.* Ә.Фәйзи. *Соңгы моментта мөдирнең йөзендә бизенү сызыклары шәүләләнде.* Х.Камалов

5) Берәр хәл яки күренеш күз алдына килү, гәүдәләнү. *Шул ук вакытта аның күз алдында тагы да зуррак борчу-михнәтләр вәгъдә итүче шомлы киләчәк шәүләләнде.* М.Галәү. *Ихтыяр, моңа кадәр һәр йорты, инеш буендагы һәрбер талы, --- бертугандай якын кешеләре аермачык булып күз алдында шәүләләнгән авылының шундый тизлек белән хәтер томаны артына кереп югала баруына шаккатып, шактый ара аңышмыйча торды.* Р.Вәлиев

**Шәүләләнә башлау** Шәүләләнү билгеләре барлыкка килү. *Авыл читләрендәге акшарлы йортлар, гөрләп үсеп торган бакчалар, төн пәрдәсе астыннан чыгып, беленер-беленмәс кенә шәүләләнә башладылар.* А.Шамов

**Шәүләләнеп китү** Берара, кыска вакытка, аз гына шәүләләнү. *Көчле пароход гәүдәсенең кысрыклавыннан ике якка аерылган сулар шәүләләнеп китәләр дә, бара-бара көчле дулкыннарга әйләнеп, Идел өстендәге чүп-чарларны читкә куалар.* Т.Гыйззәт

**Шәүләләнеп тору** Хәзерге вакытта шәүләләнү; һәрдаим яки озак вакыт дәвамында шәүләләнү. *Пәрдә ачылганда, анда бер кешенең эшләп утыруы шәүләләнеп тора.* Ә.Фәйзи. *Аның күз алдында әле һаман Фәхринең умырылган үкчәсе шәүләләнеп тора иде.* М.Галәү

**ШӘҮЛЕГӘН** *и. зоол.* Шәүлегән кошлар семьялыгыннан канатлары һәм койрыгы кара, томшыгы кызгылт коңгырт, сыерчыктан аз гына зуррак сайрар кош; яңгыр теләнчесе; *русчасы*: **иволга**. *Шунда күгәрчен кадәрлерәк бер кош – шәүлегән безнең өстебездә әйләнә-әйләнә чыелдарга тотынды.* Г.Бәширов. *Урманда яки елга буенда «фи-лү-лү» дигән моңлы тавыш ишетсәгез, ул шәүлегән булыр.* К.Тәхау

**ШӘҮЛЕГӘ́Н КОШЛАР** *и. зоол. купл.* Күбесенчә тропикларда яши торган уртача зурлыктагы сайрар кошлар семьялыгы; *русчасы*: **иволговые**

**ШӘФӘГАТЬ** *и. гар.* 1) *иск.* Берәр гаепнең гафу ителүе яки берәр теләкнең үтәлүе өчен арадашчылык. *Кыямәт көнендә күрерсең: голәмадан шәфәгать эстәрләр.* К.Насыйри. *Безгә шәфәгать сорарга урамда бер олы кеше дә юк.* Г.Камал. *Шунда ук мескен Шәрык шәфкать, шәфәгать эзләнә.* М.Гафури

2) *дини* Бәндәләрнең гөнаһларының гафу ителүе өчен, пәйгамбәрләрнең һәм изге бәндәләрнең Аллаһы Тәгалә катында арадашчы булып яклау соравы. *Пәйгамбәрләр салаватка мохтаҗдыр. Өммәтләр шәфәгатькә мохтаҗдыр.* К.Насыйри. *Мөхәммәд пәйгамбәр кешеләрне зур сулык – әл-Хауд янында каршы алачак һәм, гөнаһлары аз булган кайбер мөэминнәрне яклап, Аллаһыдан шәфәгать сораячак.* А.Тимергалин

**ШӘФӘГАТЬ ИТҮ** *ф.* Аллаһы Тәгалә катында арадашчы булып яклау сорау. *Хакыйкатьне чын күңелдән таныган-белгәннәр шәфәгать итүдән мәхрүм түгел.* К.Насыйри. *Нәкъ менә шушы төндә Аллаһ Мөхәммәд пәйгамбәргә мөселманнар өчен шәфәгать итү хокукын биргән, дип санала.* Гали Рәхим

**ШӘФӘГА́ТЬ КЫЛУ** *ф. к.* **шәфәгать итү**. *Чыннан да, төклетурадай пырылдауның бер хаҗәте дә юк хәзер. «Сабыр бирсәнә, Алла!», «Шәфәгать кыл, Рәсүлуллаһ!» дип ялварудан башка чара юк.* С.Поварисов. *Ислам диненда Кыямәт көне башлангач, Мөхәммәд пәйгамбәрнең үз өммәте өчен шәфәгать кылачагы турында мәгълүмат бар.* А.Гайнетдинов

**ШӘФӘГАТЬЧЕ** *и.* Кем өчендер шәфәгать кылучы кеше. *Ә Дәрдемәнд туры мәгънәсендә дә алтын чыгарган, татар әдәбиятын үстерүгә муллыгын һич тә кызганмаган шәфәгатьче, химаяче, меценат та ич.* М.Хуҗин. *Пәйгамбәрләр инде башка килмәс, Иң соңгысы – безнең Мөхәммәд. Шәфәгатьче булыр мөэминнәргә, Тик ул гына кылыр мәрхәмәт.* Р.Сәйфетдинов

**ШӘФӘКЪ** *и. гар.* 1) Кояш баеганнан соң офыкта кала торган кызыллык. *Яфраклары күптән коелып, шәрә ботаклары гына тырпаеп торган каен кәүсәләре тезелешеп артка очты, өсте күгелҗем боз белән капланган Пәхри елгасы шәфәкъ кызыллыгында тыптын елтырап озатып калды.* А.Вергазов. *Төннең үткәнен сизми дә калдык. Әле генә шәфәкъ баткан шикелле иде. Бактың исә, инде дөньяга яктылык сирпеп, яңа көн туып килә.* С.Сабиров

2) Кояш чыгар алдыннан офыкта пәйда була торган яктылык; таң яктысы. *Кичке шәфәкъ белән иртәнге шәфәкъ бирeдә бер үк вакытта килә, безнең Казан якларындагы шәфәкъларга да, Мәскәү тирәсендәге шәфәкъларга да һич тә охшамый иде.* Г.Әпсәләмов

3) *куч.* Нәрсәнең дә булса азагы, соңгы мизгеле. *Булсачы бер гомерем шәфәгында Сәнгать белән генә яшәргә.* Н.Арсланов

**ШӘФКАТЬ** *и. гар.* Үз итеп, яратып, кемнең дә булса хәсрәтенә, аяныч хәленә карата кичерелгән кызгану, аяу хисе, мәрхәмәт, миһербан. *Күрмәгән, белмәгән кешенең бу кадәр шәфкать һәм игътибары Гайшәне гаять шатландырды.* И.Салахов. *Бу язмамда алар язмышына кагылуым: күңел күзләребезне ачыбрак карыйк, шәфкать, мәрхәмәт, игелек эшләргә кайчан да соң түгел, дип әйтергә теләвемнән.* Ф.Яруллин

◊ **Шәфкать кулы сузу** Ярдәм кулы сузу, ярдәм итү. *– Я Яһүдә, сүзне безнең ник тотмадың, Ни сәбәптән антыбызны болай боздың, Йосыфны кызганып, шәфкать кулын суздың, Вафасызлык*

*күрсәттең ник? – диләр имди.* Кол Гали. **Шәфкать күрсәтү** *к.* **шәфкать итү**. *Ләкин язмыш Хәдичәттигә карата шәфкать күрсәтте: сугыш беткәндә, аның уллары табылды.* М.Мәһдиев. *Хаста мөгаллимәгә шәфкать күрсәтүең дә зур савап.* Н.Гыйматдинова. **Шәфкать салу** 1) *к.* **шәфкать итү**. *Безгә кылмаган золымнар калмады, Һичкем безгә шәфкатен салмады.* Ш.Мөхәммәдев; 2) Шәфкатьле итү, шәфкатьле кешегә хас сыйфатлар булдыру. *Кодрәтле Ходай күңеленә үзе аклык, ихлас җанына шәфкать салган.* Р.Мулланурова. *Безнең хезмәттә җанны рәхәтләндерә торган бер бик нык таяныч бар: ана теле, туган моң, җыр баланың күңеленә шәфкать сала.* Казан утлары. **Шәфкать кызы** *иск. к.* **шәфкать туташы**. *Шәфкать кызы Мәрьям солдат гомерен Саклаганда мина шартлады.* Ш.Маннур. **Шәфкать туташы** Медицина сестрасы. *Дежур өстәле янында йокымсырап утырган шәфкать туташы, сискәнеп, җәһәт кенә урыныннан торды да авыру янына ашыкты.* Р.Фәйзуллин. *Шәфкать туташлары курсын тәмамлагач, аны фронтка җибәрмәгәннәр, госпитальдә калдырганнар.* М.Маликова

**ШӘФКА́ТЬ ИТҮ** *ф.* Кызгану; кызганып мәрхәмәт күрсәтү. *Вә янә берничә елдан соң бәгъзы фәкыйрь-фөкара, --- җыелышып, Иван Василичтан үзләренә урын сорадылар. Иван Василич аларга шәфкать итеп, «вон вам место» дип, Яңа Бистә урынын күрсәтте.* К.Насыйри. *Инде нишлим, шәфкать итеп, Ярдәм кулын кем дә сузмагач?* Т.Гыйззәт. *Әй, ярлыка, үз кеше без, Каты булма, шәфкать ит.* Н.Исәнбәт

**ШӘФКАТЬЛЕ** *с.* 1) Кызганучан, миһербанлы, мәрхәмәтле, кешелекле, яхшы күңелле. *Борынгылар әхлак мәсьәләләрендә бик турыдан ярганнар: кем рәхимле, шәфкатьле, шул мәргән булырга, ыруга күбрәк табыш китерергә тиеш.* Р.Әхмәтьянов. *--- шигырь яраткан, шигырь язган бала ул матур күңелле, башкаларга шәфкатьле, олыларга һәм кечеләргә ихтирамлы һәм игътибарлы булып үсә.* Р.Миңнуллин

2) Миһербан, мәрхәмәт белдергән. *Наил шунда гына Тимофеичның йөзен яхшылап күрә алды. Ул туры борынлы, аксыл куе кашлы, --- күзләре зәңгәр, шәфкатьле.* Г.Әпсәләмов. *Иптәш Сафин Василий Михайлович белән кул биреп күреште, --- соңга калуы өчен гафу үтенде дә үзеннән чандыррак, тәбәнәгрәк директорның иңбашына аталарча шәфкатьле кулын тиереп алды.* Н.Фәттах

**ШӘФКАТЬЛЕЛӘНҮ** *ф.* Шәфкатьлегә әйләнү, шәфкатьле булып китү. *– Догачы бул, улым, – дия иде әнием дә, кайчан шәфкатьләләнеп.* М.Крымов

**Шәфкатьлеләнә бару** Торган саен ныграк шәфкатьлеләнү. *Ә бит картлыкта иртәдән кичкә кадәр шәфкатьлеләнә барырга кирәк!* Кызыл таң

**Шәфкатьлеләнә төшү** Бераз шәфкатьлеләнү, тагын да шәфкатьлеләнү

**Шәфкатьлеләнеп китү** Билгеле бер вакыттан, сәбәптән соң шәфкатьлеләнү. *Төнге сөйләшүдән соң хатын шәфкатьлеләнеп китте*

**ШӘФКАТЬЛЕЛЕК** *и.* Шәфкатьле кешегә хас сыйфатлар. *Тик аңарда энесенең ятим балалары хәленә керү, аларга булышу кебек изге ниятләр, киң күңеллелек, шәфкатьлелек кебек күркәм сыйфатлар юк иде.* М.Хәсәнов. *Тәрбия беркайчан да усаллык аша бирелми, шәфкатьлелек аша гына бирелә.* К.Миңлебаев

**ШӘФКАТЬСЕЗ** *с.* **1.** Мәрхәмәтсез; кызганмый торган, каты күңелле, рәхимсез, аяусыз. *Эльвирны каты күңелле, шәфкатьсез дия алмас иде Зуфирә.* М.Маликова. *Башыма ябырылып килгән шәфкатьсез уйлардан талатып, атналар буе монда да ятмас идем.* А.Вергазов. *Мәгәр вакыт адәм баласының мәнфәгатьләренә битараф, ул гына да түгел, рәхимсез, шәфкатьсез.* Т.Галиуллин

**2.** *рәв. мәгъ.* Аяусыз рәвештә, җәлләмичә, кызганусыз, мәрхәмәтсез, рәхимсезләнеп. *Коллар баш күтәрде, алар иске тормышны диңгез төбенә батырырга тиешләр. Ләкин моның өчен --- батыр егетләр кирәк, --- шәфкатьсез сугыша торган нык халык кирәк.* Г.Әпсәләмов. *Рушад --- диңгезнең кургаш суын миллиард бөртеккә әйләндереп, кара сыртын шәфкатьсез рәвештә елтыратып килгән үлем машинасы – торпеданы күргән иде.* М.Мәһдиев

**ШӘФКАТЬСЕЗЛЕК** *и.* Шәфкатьсез булу сыйфаты, рәхимсезлек. *Кызганыч ки, тотрыксыз бу елларда яратудан бигрәк шәфкатьсезлек күреп үсә балалар.* Ш.Галиев. *Тормыштагы миһербансызлыкка, кансызлыкка бәрелеп, күп тырышлыкларыбыз челпәрәмә килә. Шәфкатьсезлек чүп үләне кебек үрчи.* Ф.Яруллин

**ШӘФТАЛУ** *и. фар. бот.* 1) Гөлчәчәклеләр семьялыгыннан киң ябалдашлы, озынча яфраклы, алсу яки кызыл чәчәк ата торган тропик агач; *русчасы:* **персик**. *Хәтта нинди бай Алманиядәгедән дә мулрак монда, чөнки армут, анар, банан, йөзем, шәфталу, тагын башкалар барысы да үзендә үсә.* Т.Әйди. *Кайчак яңашәдә генә җете яшел куаклыклар, шау җимешкә күмелеп утыручы абрикос, шәфталу, чия агачлары утырып кала.* Л.Гыймадиева

2) Шул үсемлекнең саргылт-кызгылт төстәге татлы, итләч, сусыл җимеше. *Сәгъдәтнең кайгыртучанлыгы белән табыныбызга борыч, кәбаб, шәфталу суты, катык килә.* Т.Әйди. *Сумкасына йөзем, шәфталу, инҗир кебек җылы як җимешләре тутырган Хәбибә базардан кайтып килә иде.* Ф.Абдуллин

**ШӘХЕС** *и. гар.* 1) Үзенә генә хас холыкка, үзенчәлекле сыйфатлары булган характерга ия кеше, зат, индивидуум. *Әсфәндиярова --- берсе икенчесенә охшаган геройларны башкарганда да, нииндидер эчке уртаклыклары булуга да карамастан, аларның һәрберсен индивидуаль шәхес итеп тоя.* И.Илялова. *Кешене шәхес буларак ихтирам итү*

2) Җәмгыятьнең бер әгъзасы, аерым бер кеше. *Сыйнфый нәфрәт белән сугарылган бу идеология күпләрнең аңына гына түгел, канына үтеп керде. Шәхес иреге һәм фикер хөрлеге дигән төшенчәләрне юкка чыгарды.* Ә.Еники. *Каюм Насыйриның эчтәлеге һәм төзелеше буенча да бай, күпкырлы әлеге хезмәте, нигездә, бер максатка – төрле яктан үскән, мәгърифәтле, камил әхлаклы шәхес тәрбияләүгә юнәлтелгән.* Фән һәм тел // Берәр эшчәнлек өлкәсендә дан казанган, исеме булган, эз калдырган кеше. *Биредә шулай ук Ворошилов, Орджоникидзе кебек танылган шәхесләр дә була ---.* Ф.Бәйрәмова

3) Берәүнең кешелек дәрәҗәсе, горурлыгы

◊ **Шәхескә тию** Рәнҗетү, кимсетү, түбәнсетү, дәрәҗәсен төшерү. *Мәсләк аерымлыгыннан килеп чыккан бәхәсләр барышында бәхәсләшүчеләр, вакыт-вакыт төп темадан читкә китеп, берберсенең шәхесенә тия торган сүзләр әйтешүгә кадәр барып җитәләр.* Ф.Ибраһимова. **Шәхес культы** Җәмгыять тарихында теге яки бу тарихи шәхесне идеаллаштыру, табыну объектына әйләндерү. *Ләкин бит инде Сталин үлгәнгә тугыз ел, XX съездда Сталинның шәхес культын тәнкыйть иткәнгә дә алты ел, нигә һаман шул хәл әле?*

М.Мәһдиев. *Шәхес культына бәйле булган сәяси торгынлыкның чигенә башлаган чоры.* Л.Хәмидуллин

**ШӘ́ХСӘН** *рәв. гар.* Нindидер бер аерым кешенең үзе; аерып алып. *Әнә бит мәшһүр Леонардо да Винчиның «Джоконда»сын ничек мактыйлар. Мактасыннар. Берәүгә дә киресен исбатларга җыенмыйм, ә шәхсән үзем Джоконданы һич кенә дә матур димәс идем.* Н.Әхмәдиев. *Туфайлов аек акыл белән уйлап белә, бу эш шәхсән аның өчен минус булачак, үз башына бәлаләр дә ясавы мөмкин.* Х.Камалов

**ШӘХСИ** *с. гар.* 1) Кешенең холкына хас булган; индивидуаль. *Рәмиевнең зур осталык белән истә калырлык, көчле шәхси сыйфатларга ия булган характерлар тудыруын билгели.* Т.Гыйләҗев

2) Шәхеснең рухи тормышына, күңеленә, кичерешләренә караган. *Һаман игътибар үзәгендә кайнарга күнеккән зат өчен ялгызлык үзе бер җәза булса, шәхси борчылулар да килеп кушылгач, ул җәза түзә алмастай сагышка әйләнә икән.* М.Әмирханов

3) Кешенең үз тәҗрибәсенә, гомеренә, тормышына мөнәсәбәтле; үз. *Ринат әфәнде, шәхси планнарыгыз турында да бер-ике сүз әйтеп үтсәгез иде.* Ю.Сафиуллин. *Иҗтимагый-сәяси көрәштә вакытлы матбугатның ролен шәхси тәҗрибәсендә тирәнтен аңлаган Гаяз Исхакый 1928 елгы Варшава корылтаенда гәзит-журналлар чыгару бурычын бөтен кискенлеге белән куя.* Х.Миңнегулов

4) Аерым бер кеше өчен билгеләнгән, бер кеше генә кулланган. *Курсантларга шәхси әйберләрен һәм коралларын гына түгел, курсларның барлык җиһаздирбиясен үз иңнәрендә күтәреп барырга кирәк була.* Р.Мостафин

5) *ялг.* Бер кешенең карамагында, милкендә булган; хосусый. *Җирне шундый яратабыз, Шәхси милек итәбез: Китмәскә дип киләбез дә Килмәскә дип китәбез.* Р.Миңнуллин

6) Аерым бер шәхеснең гаилә мөнәсәбәтләре белән бәйле булган. *Ә менә ике көн мин囲 эштә утырам, шәхси тормышым турында уйлыйм.* М.Мәһдиев. *Мира кебек уңган, акыллы хатын шәхси бәхетен табарга хаклы.* Х.Камалов

7) Билгеле шәхес тормышка ашырган, шул шәхестән чыккан. *Башкаларны Ватанны сакларга җибәрү буенча көне-төне үгетләсә дә, шәхси үрнәк күрсәтергә никтер ашыкмады Мидхәт.* Н.Әхмәдиев. *Бөтен эш аерым шәхесләрнең шәхси инициативасы белән җан асрарга киткән вакыт, хезмәт исәбенә бара.* И.Әмирхан

**ШӘХСИ́ЯН** *рәв. гар. иск. к.* **шәхсән**. *Зөфәр үзе дә хәзергә һични турында сорашмыйча, шәхсиян нинди тәэсир алачагын белер өчен, бары үз күзе белән генә карап узарга тели иде.* Ә.Еники. *– Хәер, бу сезнең шәхсиян үз эшегез, – диде күңелсезләнеп Идрис.* А.Гыйләҗев

**ШӘХСИЯТ** *и. гар. иск.* 1) Кайсы да булса бер шәхесне башкалардан аерып торган үзенчәлекләр, сыйфатлар; индивидуальлек. *Кызлар иркә, Ирләр күркә, Хатыннар курчак – Аңкый шәхсият!* Ш.Бабич. *Алтын Урдадан соң оешкан ханлыкларда да өстен тотылган шәхсият татарлык түгел, мөселманлык була. Көнбатышта да, көнчыгышта да милли түгел, дини шәхсият өстен тотылган Урта гасырларда бу – гаять табигый хәл.* М.Өнәр

2) Үз файдасын гына кайгыртучанлык; эгоистлык. *Монда фәкать шәхсият вә дөньяви гараз.* Г.Тукай

**ШӘҺАДӘ́Т** *и. гар.* 1) *иск.* Шаһитлык, гуаһлык, таныклау эше. *Син ни белдең? Кемгә мәкъбүл шәһадәтең?* Г.Тукай

2) Мөселман булуның беренче шарты булган «Әшһәдү әл-лә илаһә иллаллаһ вә әшһәдү әннә Мөхәммәдән габдүһү вә рәсүлүһ» (Аллаһтан башка илаһ юк, Мөхәммәд – аның колы һәм илчесе) җөмләсен әйтеп иман китерү гамәле. *Нури бабай да биш вакыт намазын, шуның дәрәҗәсендә үк үзенә бурыч итеп белгән зикерләрен, вирдләрен калдырмау гына түгел, --- тәүбәсен, шәһадәтен яңарта тора.* Г.Ибраһимов. *Мотыйгулла ахун хәзрәт белән Мирхәйдәр мулла кыз ишерелгән йортка барып, Анастасияне кире Җанбикәчкә кайтарып, тәүбә иттереп, шәһадәт догасын вә башка сүрәләр укытып, исламга дүндереп кайттылар.* Р.Батулла

◊ **Шәһадәт бирү** 1) Гуаһ булу, шаһит булу, раслау. *Атасы Җәләл хәзрәтнең шүрлегендә өелеп яткан китаплар да аның раслыгына шәһадәт бирәләр.* Г.Ибраһимов; 2) *к.* **шәһадәт китерү** (*1 мәгъ.*). *Аллаһның ризалыгына ирештерәчәк икесе: Аллаһтан башка тәңре юк дип шәһадәт бирүегез һәм гөнаһларыгызны ярлыкавын соравыгыз.* Кызыл таң. **Шәһадәт китерү** 1) «Әшһәдү әл-лә илаһә иллаллаһ вә әшһәдү әннә Мөхәммәдән габдүһү вә рәсүлүһ» (Аллаһтан башка илаһ юк, Мөхәммәд – аның колы һәм илчесе) җөмләсен тавыш белән уку. *Аллаһның берлегенә шәһадәт китерү*; 2) Ислам динен кабул итү. *Шулчагында Аллаһы пәйгамбәргә ярдәмгә Җәбраил фәрештәне иңдерә. Моны күргәч, кяферләр шәһадәт китерәләр, ун мең яһүд мөселманлыкка чыга.* А.Тимергалин

**ШӘҺАДӘ́Т БАРМАГЫ** *и.* Имән бармак. *[Фәтхулла хәзрәт] акрын гына Әхмәтнең колагына бөкрәеп, шәһадәт бармагы белән күрше ложадагы бер даманы күрсәтә.* Ф.Әмирхан

**ШӘҺАДӘ́Т ИТҮ** *ф.* Таныклык кылу, таныклык итү, шаһитлык итү

**ШӘҺАДӘТНАМӘ** *и. гар.-фар.* Юридик әһәмияткә ия булган берәр фактны раслый яки шәхеснең нәрсәгә дә булса хокукын күрсәтә торган рәсми документ, таныклык. *Синең шәһадәтнамәңне әткәйләр кулыннан алып карарга уңайсызландым, шуның өчен нинди фәннәрдән имтихан тотканыңны белә алмадым.* Г.Мөхәммәдова

**ШӘҺӘР** *и. фар.* 1) Сәнәгать, сәүдә, мәдәният үзәге булган һәм күп кеше яши торган эре административ торак пункт; кала. *Миллионлы шәһәр Казанның үтә тыйнак вокзалыннан соң сазлыклар, урманнар уртасында урнашкан, халкы йөз меңгә дә җитмәгән Тубыл өчен мондый корылма миңа артык тәкәббер һәм көяз тоелды.* Т.Әйди. *Алар кайнап торган шәһәр урамнарының, трамвай-троллейбус тукталышының кайсында гына очрашмасыннар, шундук бер-берсен әллә каян күреп алалар ---.* М.Маликова // Шул торакның үзәге, үзәк урамнары, бистәләрдән башка өлеше. *Көн артыннан көн уза, әтием белән Касыйм абый көндезләрен шәһәргә чыгып, базар тирәләреннән, үзәк урамнардан, мәйданнардан йөреп кайталар.* Ф.Әмирхан. *Ял көннәрендә, мине ияртеп, шәһәргә чыга, урам әйләндерә һәм, хуҗаларча эре-эре атлап, иң олы кибеткә килеп керә.* Т.Галиуллин

2) Шул торак пунктта яшәүче халык. *Каладан утарга таба кузгалган көнне күк йөзе чалт аяз, мөлдерәп кояш чыккан, шәһәр уянган иде инде.* М.Хәбибуллин. *Менә бермәл бөтен шәһәр йокыга талган.* Ф.Яруллин

**ШӘҺӘ́РАРА** *с.* Шәһәрләр арасындагы, шәһәрләрне үзара бәйли торган. *Икенче көнне таңнан Әлифә шәһәрара телефон станциясенә йөгерде.* М.Маликова. *Мин, Идрис, шәһәрара йөкләр*

*ташучы машинада эшлим, ягъни ерак рейсларга йөрим*. Р.Кәрами

**ШӘҺӘРЛӘШҮ** I *ф.* 1) Илнең икътисади һәм мәдәни тормышы үзәк шәһәрләрдә туплану; шәһәрләр күбәю һәм үсү. *Төрмә (зиндан) күчмә тормыш шартларында түгел, бәлки шәһәрләшкән, үзәкләшкән дәүләттә генә барлыкка килә ала*. Н.Фәттах

2) Шәһәр кешесенә әйләнү, шәһәр кешеләре тормышын һәм гадәтләрен үзләштерү, шәһәрчә тормыш белән яши башлау. *Шәһәрләшкән алпавыт җәйләрен шушы мәһабәт агач йортта, сирень бакчасы эчендә яшәгән*. М.Мәһдиев. *Әллә соң телебез шәһәрләшә, заман тизлегенә яраша алмыймы, аңыбыз бу чуар дөньяны кабул итәргә әзер түгелме?* М.Галиев

**Шәһәрләшә бару** Аз-азлап, акрынлап шәһәрләшү. *Буржуаз әдәби телгә күп шивәләргә аерылган крестьян һәм авылдан чыгып шәһәрләшә барган пролетариат теле каршы куела*. Г.Алпаров. *Мин дә шәһәрләшә барам, Шулай тиеш, янәсе...* Г.Морат

**Шәһәрләшә башлау** Шәһәрләшү билгеләре күренү. *Хәбиб акрынлап авыл белән элемтәне өзде, шәһәрләшә башлады*. М.Мәһдиев. *Ул тулы йөзле, уртача буйлы, берәр ел элек авылдан килгән татар кызы, ахры. Әмма шәһәрләшә башлаган: кыска җиңле җәйге кофта, тездән чак кына түбән итәк, чәче киселгән*. Р.Кәрами

**Шәһәрләшеп бару** *к.* **шәһәрләшә бару**. *Бүген, бер караганда, безнеке кебек шәһәрләшеп барган авылларда яшәп тә була кебек*. Ватаным Татарстан. *Шәһәрләшеп барабыз дисәк тә, авыл җирлегендә киез итек кимичә булмый*. Ирек мәйданы

**Шәһәрләшеп бетү** Бөтенләй шәһәрләшү. *Шәһәрләшеп беттем инде тәмам... Кыска итәк, биек үкчә киям*. Ш.Җиһангирова. *Хәзер шәһәрләшеп беттек: капкалар тимердән, коймалар биек, моңа кадәр бик тә күрмәгән ишектә – йозак*. Шәһри Казан

**Шәһәрләшеп җитү** *к.* **шәһәрләшеп бетү**. *Элеккеге сталинист пенсионерларга алмашка татар мәктәпләрен бетергән, ниһаять, шәһәрләшеп җиткән яңа татар пенсионерлары буены килә*. Мирас

**Шәһәрләшеп китү** Билгеле бер вакыттан, вакыйгадан соң шәһәрләшү; сизелерлек шәһәрләшү. *Авылда туып үссә дә, бик тиз шәһәрләшеп киткән, тез тиңентен кара итәк, зәңгәр блузка киеп, берет-кепканы кыңгыр салып йөри торган Наҗия --- тәмәке кабызып җибәрә*. Г.Ахунов. *Бераз гына твист биеп алдык, Керәп-керәп чыктык ресторанга... Шәһәрләшеп киттек бик тиз шулай*. Х.Әюп

**ШӘҺӘРЛӘШҮ** II *и.* Илнең икътисади һәм мәдәни тормышының эре шәһәрләрдә туплану күренеше; урбанизация. *Шәһәрләшү (урбанизация) халыкның рухи дөньясына да бик зур йогынты ясый*. Ә.Еники. *Советлар тарихының бөтен чорында татарларның эре шәһәрләргә туплануы көчәйде. Әгәр XX гасыр башында ул 5 кенә процент булса, 1980 елларда татарларның шәһәрләшүе 70 процентка җитә*. М.Хәсәнов

2) Шәһәр кешесенә әйләнү, шәһәр кешеләре тормышын һәм гадәтләрен үзләштерү дәрәҗәсе, шәһәрчә тормыш белән яши башлау рәвеше. *Равил исә үзенең шушындый данлавы белән заманга, шәһәрләшү һәм милли сыйфатларны югалту реаль куркыныч булган шартларга гомумиләштерү ясый*. Н.Хисамов. *Литва татарларында шәһәрләшү дәрәҗәсе шактый югары булган ---*. Д.Исхаков

**ШӘҺӘРЛЕК** *и.* 1) Шәһәр кешесенә хас сыйфатларга, шәһәр гадәтләренә ия булу; шәһәрчәлек. *--- сез бит авыл малае, ә минә сезнең хатыныгыз – шәһәр кызы, Казан кызы. Гаиләдә, үзегез дә әйттегез, төрлесе булырга мөмкин. Менә шул авыллык белән шәһәрлек комачауламадымы яшьрәк чакларда?* Р.Миңнуллин. *Кешенең кием-салымы, кыяфәтендә дә авыллык та, шәһәрлек тә күренә*. Ш.Галиев

2) Шәһәр буларак алга китү, үсеш дәрәҗәсе; шәһәр кыяфәте. *Мәдрәсәләрен яндырды, Коръән-китапны җыеп яндырды, йортларын вәйран итте. Шәһәрлек сыйфаты бер дә калмады*. К.Насыйри. *Алабуга да соңгы елларда шактый үзгәрде, шәһәрлеге артты*. Р.Рахман

3) *археол.* Элек шәһәр булган, борынгы шәһәр яисә ныгытмаларның эзе, калдыклары сакланган урын; *русчасы*: **городище**. *Галимнәр әйтүенчә, Аркаимнан Варнага кадәр 70–80 чакрым арада дистәләгән борынгы шәһәрлекләр булган. Тамерлан манарасы да шул шәһәрлекләрнең, шул борынгы тормышның бер кыйпылчыгы, соңгы билгесе булырга тиеш*. Ф.Бәйрәмова

**ШӘҺӘ́РЧӘ** *рәв.* **1.** Шәһәрдәге кебек, шәһәр гадәтенчә, шәһәр тормышына хас булганча. *Без шәһәрчә сөйләшергә өйрәнмәгән*. Г.Бәширов. *Исхак аңлатып бирергә җыенган иде, киселгән капкара чәчле, шәһәрчә киенгән кызның да кычытканлыкка үрелүен күреп, капылт тагын чүгәләде*. А.Гыйләҗев

**2.** *с. мәгъ.* Шәһәрнекенә охшаган. *Аның өстендәге шәһәрчә киемнәре, бигрәк тә аягындагы кыска ак ботинка белән башындагы ак камыш эшләпәсе аңа әллә нинди зур төс бирәләр*. Г.Ибраһимов. *Шәһәрчә озын пәлтәле, үкчәле ботинка кигән бу хатын авыл урамына бер дә ятышмый, баш киеме дә әллә нинди үзгә, ят аның*. Г.Әдһәмова

**ШӘҺӘ́РЧӘЛӘНҮ** *ф.* Шәһәрчәгә әйләнү, шәһәрнекенә охшау. *Кызның кием-салымы шәһәрчәләнгән иде*

**Шәһәрчәләнә бару** Аз-азлап, акрынлап шәһәрчәләнү. *[Нефтьчеләр яшәгән авылларда] кием-салым, өй җиһазлары, гореф-гадәт тә шулай акрынлап, ничектер үзеннән-үзе шәһәрчәләнеп бара*. Г.Бәширов

**Шәһәрчәләнә төшү** Бераз шәһәрчәләнү; тагын да шәһәрчәләнү

**ШӘҺӘРЧӘЛЕК** *и.* 1) Кешенең үзен тотуында шәһәр гадәтләре, шәһәр тәрбиясе. *Шәһәрчәлекнең бөтен ягы килсен дип, аякларны да аның җаена [Лена кушканча] атларга көйлим, барып чыкмый*. Ә.Баян. *Хәмәт исә Самат характерының шәһәрчәрәк варианты иде бугай. Анда шәһәрчәлек, иркенлек, кыюлык күбрәк иде*. М.Вәлиев

2) Шәһәр кыяфәте, шәһәрчә үсү дәрәҗәсе, шәһәр билгеләре. *Башлап күзгә бәрелгәне – шәһәрчәлек: тигез, киң аллеялар, чәчәк түтәлләре, көймәле арбалар*. Җ.Рәхимов

3) Шәһәрдә кабул ителгән тормыш рәвеше. *Бусагадан атлап керүгә, шәһәрчәлек, пөхтәлек күзгә ташлана: идәндә – затлы палас, түрдә – келәм белән ябылган кәнәфи; ян тәрәзә каршында – тартмалы язу өстәле, өстәл өстендә, киштәләрдә – рәт-рәт итеп тезелгән китаплар*. Т.Мөбарәков

**ШӘҺӘРЧЕК** *и.* 1) Зур булмаган шәһәр, кечкенә шәһәр. *Ул арада төзек йортлары белән шәһәрчеккә тартым бер матур посёлокка килеп керделәр*. А.Хәсәнов. *Ә менә Чехиядә урнашкан кечкенә генә шәһәрчектә яшәүче халыкка рәхәт – Карловы Варының үз радиосы һәм телевидениесе көне-төне эшләп, күрсәтеп, сөйләп тора*. Б.Рәхимова

2) Бер максатка хезмәт иткән аерым учреждение, бина һ.б.ш. комплексы.

*Без хәрбиләр шәһәрчегендә торганда, әти балаларны җыяр иде дә олимпия уеннары оештырыр иде.* А.Гыйләҗев. *Самолёт төзүчеләр шәһәрчеген узып, бүлнискә кереп барам.* В.Нуриев

**ШӘҺӘРЧЕЛЕК** *и.* 1) Илнең матди һәм рухи мәдәниятен эре шәһәрләргә генә туплауны яклаучы агым; урбанизм

2) Шәһәрне, шәһәр тормышын ярату. *Җомагыл, тагын үзенең шәһәрчелек роленә керешеп: – Шәһәргә иянәнеп китсәгез, совхоз төштәге төсле генә калыр, – ди.* Ф.Сәйфи-Казанлы

3) *махс.* Әдәбият һәм сәнгатьтә шәһәр стихиясе мотивларына өстенлек биргән юнәлеш

**ШӘҺВӘТ** *и. гар. кит.* Каршы җенескә карата җенси дәрт, көчле теләк. *Үзе балалык мәртәбәсеннән чыкмыйча, --- өйләнү хәерле нәтиҗә бирми. Бары хайвани шәһвәт, тән ләззәте үтәү өчен генә бер гамәл булып чыга.* Г.Баруди. *--- кызның ләззәт вәгъдә иткән ымсындырулы карашын тоюга, --- ул тагын ташкын хисләре коллыгында бер мәхлук хәлендә кала. --- Көннән-көн тирәнрәк суыра барган бу чоңгылдан ничек котылырга, шәһвәтенә ничек баш булырга?* Н.Әхмәдиев

**ШӘҺВӘТЛЕ** *с.* Шәһвәте көчле булган, шәһвәт белән тулы. *Комедиянең асылы шунда ки, шаян яшьләр, Юныс Хаҗиның шәһвәтле нәфесләреннән көлеп, аны яшь мөгаллимә урынына үз хатыны Галимә карчыкка «өйләндерәләр».* К.Гыйззәтов

**ШӘҺИД** *и. гар.* 1) *дини* Аллаһ юлында һәм дин өчен сугыш барышында үлгән кеше. *Бөтен әүлиялар, бөтен пәйгамбәрләр, дин юлында шәһид булган бөтен мөселманнар, еглый-еглый күзләре беткән, агарга яше кипкән шул хатынга шәфагатьче бул, бул!* Г.Исхакый

2) Ватан, милләт, изге максат яки бурыч өчен үлгән кеше

◊ **Шәһид китү** Иманы, ватаны һәм изге максаты яки бурычы өчен сугышканда үлү. *Моңарчы шәкертләренә гел игелек, гел миһербан турында гына вәгазь укыган имам Кол Шәриф бүген шәкертләрен кылычка тотынырга, Ватанны дошманнан саклап шәһид китәргә чакыра.* Р.Батулла

**ШӘҺИДЛЕК** *и.* 1) Шәһид гамәле. *[Габдулла:] Аллаһы Тәгалә шуларның барысына да шәһидлек савабы язсын!* Г.Исхакый

2) Шәһидләр җирләнгән зират, каберлек

**ШВА́БРА** *и. нем.* Нечкә баулар, сүс, чүпрәк яки мунчала кебек нәрсәне таякка беркетеп эшләнгән идән юу әсбабы. *Без бөтен экипаж белән куллафрыбызга көрәкләр алып, бу кадерсез пассажирларны көрәк белән көрәп, швабралар белән себереп, диңгезгә ташларга мәҗбүр булдык.* А.Хәсәнов. *--- Ниса апа --- швабрасын сулы чиләктә сыга-сыга һәм болында печән чапкан ирләр кебек селтәнә-селтәнә, озын коридорларның идәннәрен юарга керешә.* Т.Нурмөхәммәдев

**ШВЕД** *и.* Һинд-европа телләр семьясының скандинав группасына караган телдә сөйләшүче һәм башлыча Швециядә яшәүче төп халык һәм шуның бер кешесе. *Швед галиме Тур Хейердал илленче елларда Пасха атавында шул тамгалар төшерелгән дәфтәрләр таба.* А.Тимергалин. *– Ә җирле халык, ягъни папуаслар кайда яши? – дип кызыксынуында булды швед.* Р.Мөхәммәдиев

**ШВЕ́ДЧА** *рәв.* Швед телендә. *--- алманча, финча, төрекчә, шведча, инглизчә, урысча иркен сөйләшкән, кытайча һәм гарәпчә аңлаган милләттәшемнең минем алда абруе бик югары.* Т.Әйди

**ШВЕЙЦАР** I *и. нем.* Кунакханә, ресторан, аерым учреждение ишек төбендә кизү торучы хезмәтче, хадим. *Тулай торакка кадәр ул бик батыр килде, ишекне дә кыю гына ачты, эчкә керде. Ишек катында аны швейцар хатыннар туктатты.* А.Гыйләҗев. *Германиядән Нью-Йоркка пароход белән төяп алып кайткан татар егетләрен башта һотельләргә, бишәр йолдызлы кунакханәләргә швейцарлар итеп урнаштырганнар.* А.Хәсәнов

**ШВЕЙЦАР** II *и. ялг. к.* **швецарияле**. *– Я, я, Зарифуллин... Аны сөйләргә кыенсынсаң, Иоганн Генрих Песталоцци карашларына туктал. Бөек швейцар педагогының баланы тәрәккый иттерү турындагы карашлары нидән гыйбарәт?* М.Мәһдиев. *– Минем дә сезгә бүләгем бар, – дип, --- «дипломат»ын ачты. Бу – швейцар сәгате, --- сезгә ошар дип ышанам ---.* Р.Мирхәйдәров

**ШВЕЙЦА́РИЯЛЕ** *и.* Швейцариядә яшәүче, немец, француз, итальян һәм ретророман телләрендә сөйләшүче халык һәм шуның бер вәкиле

**ШЕВИОТ** *и. ингл.* **1.** Өске кием тегү өчен кулланыла торган артык калын булмаган, йомшак, җиңел йон яки ярымйон тукыма. *Ике-өч минуттан соң идарәдәге тимер сандык өстендә шевиот, трико, бостон һәм башка чүпрәк-чапраклар өелеп ята иде инде.* Р.Батулла. *13 сум 70 тиенгә шевиот дигән материалдан концерт костюмы да тектереп җибәрдем әле получкадан.* Т.Нәҗмиев

**2.** *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән. *Гыймай абыйның өстендә Сафа абый тегеп биргән шевиот бишмәт, башында шул элекке малорус диган озын бүрек.* Г.Бәширов. *Бәдри --- колхозда эш бетүгә --- әллә кай якларга чыгып китә һәм май бәйрәме алдыннан гына, кап-кара шевиот костюм, сары штиблетлар киеп, авылга кайтып төшә ---.* М.Мәһдиев

**ШЕВРЕТ** *и. фр.* **1.** Кәҗә яки сарык тиресеннән эшләнгән хром күн

**2.** *с. мәгъ.* Шундый күннән тегелгән. *Шеврет ботинкалардан йөрү. Шеврет куртка тектерү*

**ШЕВРО** *и. фр.* **1.** Кәҗә тиресеннән эшләнгән йомшак хром күн

**2.** *с. мәгъ.* Шундый күннән тегелгән. *Шевро күн. Шевро итекләр*

**ШЕВРОН** *и. фр. хәрби* Хәрбиләр (солдат һәм кече офицерлар) киеменең сул җиңендә хезмәт срогыннан тыш ничә ел хезмәт итүен белдерә торган почмак формасындагы галун, шнур яки тасма тегелмә. *Билетын исәпкә алдырган чиратта Зуфирә бер диңгезче артына туры килде. Зәңгәр китель җиңенә өч сары тасма – шеврон тегелгән иде. «Капитан», – дип уйлады Зуфирә.* М.Маликова // Бөек Ватан сугышы вакытында яраланганлыкны белдерү өчен уң күкрәккә тегелә торган кызыл яки алтын төстәге тасма

**ШЕДЕВР** *и. фр.* 1) Осталык үрнәге булырлык иң югары дәрәҗәдәге, сокланырлык сәнгать әсәре; шаһәсәр. *Дөнья сәнгатенең шедевры Венера Милосская статуясы бу, Рамазан абый. Безнең эрага кадәр үк антик культура иҗаты.* И.Юзеев. *Нишләп соң без шушы бәһа биреп бетермәслек рухи байлыгыбызны, дөньяга күрсәтердәй музыкаль шедеврларыбызны сандыкка бикләп саклыйбыз.* Р.Вәлиев

2) *ирон.* Тиешле профессиональ дәрәҗәдә булмаган, түбән сыйфатлы, начар, чиле-пешле, булыр-булмас нәрсә. *– Укыдым да төсле кызыгызның шедеврларын. – Я, өметлеме? – Кызларның нәрсә инде, шул бәхетсез мәхәббәт, әнкәсен сагыну, Мәрзия ханым.* Н.Гыйматдинова. *Хәзер композиторлар үзләре текст язалар, көй чыгаралар, үзләре җырлыйлар. Бәлки, кайберәү-*

*ләрне хисләндерәдер, әмма ул «шедевр»-ларда логик фикер, уй юк.* Р.Фәйзуллин

**ШЕЗЛОНГ** *и. фр.* Арканы сөяп ярым ятып тору өчен материя тарттырылган җиңел, күчерелмәле урындык. *Кемнәрдер камыш урындыкларны, шезлонгларны кояшка тартып чыгарып, ярым чишенгән хәлдә сузылышып яттылар.* А.Гыйләҗев. --- *койма буенда куерып үскән кычытканнар ышыгындагы шезлонгында, мүкләнгән олы таш сыман, көннәр буена кузгалырга иренеп ята торган иде.* А.Юнысова

**ШЕЙК** *и. ингл.* Гәүдә һәм җилкәләрне уйнаклаткан кебек кызу хәрәкәтләр ясап бии торган парлы бию һәм шул бию өчен махсус язылган музыка. *Эстрада оркестры уйнап тора, егетләр, кызлар соңгы модадагы шейк, твистларны әйттерәләр генә.* Н.Әхмәдиев. *Баянчы шейк уйный. Альфред белән Римма, бөгелә-сыгыла, шейк биилә.* Ш.Хөсәенов

**ШЕЛЛАК** *и. голл.* 1) Кайбер тропик агачларда паразитлык итә торган бөҗәкләр эшләп чыгарган, лак, сургыч кебек нәрсәләр өчен чимал булып хезмәт иткән табигый сумала. *Шеллак үзе зыянлы түгел, ә менә аны чистартканда кулланыла торган махсус эремәләр тырнакларны бозарга мөмкин.* Мәйдан

2) Маникюрда кулланылган гель-лак төре һәм шуның белән эшләнелгән маникюрның үзе. *Соңгы вакытта маникюрны шеллак белән ясыйлар.* Саба таңнары

**ШЕЛТӘ** *и.* 1) Кемгә дә булса карата үпкә, ризасызлык хисе. *Гәрәйнең --- тышка таба чыгып торган күзләре, гәүдә җил белән әйләнгән саен әле бер якка, әле икенче якка карыйлар, бу күзләрдә шелтә катнаш шашкынлык белән каты газап тулы.* Г.Ибраһимов. *Профессор тирән шелтә белән башын селекте.* Г.Әпсәләмов

2) Шул хисне белдергән сүзләр. *Иң беренче эше итеп Мохтар, урамга йөзен капламыйча чыкканы өчен, Саҗидәгә шелтә белдерде һәм чын түрәләрчә кырыс тавыш белән аңа моннан соң йөзен гел каплап йөрергә боерды.* М.Галәү. *– Күзгә төртсәң күренмәслек караңгыда җүнле кешенең эте дә урамга чыкмый бит, – дип, Нәсыйх аны шелтә белән каршылады.* В.Имамов

3) Оешма, учреждение администрациясе һ.б.ш. тарафыннан аерым шәхескә бирелә торган рәсми җәза төре. *Шунысы кызык: ул чакта, икмәген яшереп калдырган дип, бюрога чакыртып, миңа каты шелтә бирделәр.* В.Нуруллин. *Татарстан өлкә комитеты җитәкчелеге, алар әләгенә нигезләнеп, милләт өчен артык тырышкан Зәки Нуригә язма рәвештә шелтә белдерә.* Л.Хәмидуллин

◊ **Шелтә ташлау** *к.* **шелтә ясау**. *Нигъмәт аңа каршы шелтә ташлады: – Әхтәм, бу ни эшең синең? Кешенең ни әйтәчәген белмисең, алдан бәйләнергә тотынасың?* Г.Ибраһимов. **Шелтә ясау** Шелтәләү, ачулану, тиргәү. *Мине күреп алгач: – Әле син, җегет кисәге, балалы хатын кебек, һаман өйдә маташасың икән, – диде. Миңа йомшак тавыш белән генә шелтә ясап алды.* Ә.Еники

**ШЕЛТӘЛӘ́Ү** *ф.* 1) Кимчелеген күрсәтеп кисәтү; ярамаган эш эшләгән өчен әрләү, тиргәү. *– Мин бай булсам, бөтен байларга үрнәк булырлык эш тә итәр идем һәм тора да белер идем, хәзерге байлар нәрсә ул... Байлыкның кадерен белмиләр, рәхәтләнә дә алмыйлар, – дигән шикелле сүзләр белән һәрвакытта байларны тирги, шелтәли иде.* К.Тинчурин. *Мин Әмирне шелтәлим: – Әллә кайда йөрисең? Митингны башларга унбиш минут вакыт калды, ә син юк!* З.Зәйнуллин

2) Шелтә (*3 мәгъ.*) белдерү. *Синең киемең, аяк атлавың, кыланышың, хәтта фикерләреңә кадәр устав куйган таләпләргә тәңгәл булырга тиеш. ---Устав куйган таләпләр үтәлмәгән очракта, сине үзеңнән югарырак чинлы һәр офицер, синнән өстен һәр начальник шелтәли ала.* М.Юныс

**Шелтәләп алу** Бераз шелтәләү. *Без Габдерәхимне шелтәләп алдык: – Нигә алдыйсың, килмиләр ич, басып торалар... – дидек.* Ә.Еники. *Касыйм ага шатланып елмайды һәм карчыгын җиңелчә генә шелтәләп алды.* Р.Кәрами

**Шелтәләп карау** Шелтәләргә омтылу, шелтәләп аңлатырга тырышу. *Үзебез – авыл кешеләре – аучыларга кисәтү ясап, шелтәләп караган идек, кая ул!* Якты юл

**Шелтәләп килү** Күптәннән бирле даими шелтәләү. *Гайнетдинов сүзен шулай бетерде: – Дөрес, мин Салахиевны һаман шелтәләп килдем. --- Син начар большевик дип чәнчә тордым мин аны!* Г.Ибраһимов

**Шелтәләп китү** Сүз уңаеннан, җиңелчә генә шелтәләү. *– Син бүген җиренә җиткереп саумадың, – дип, Ибәтулла абзый шелтәләп китте. – Соңынтын терлекчеләр йортына кер.* Н.Гыйматдинова

**Шелтәләп кую** Кинәт, көтмәгәндә, бер тапкыр шелтә белдерү. *Әшләпәле кеше саф татар телендә, кирәкмәгән кешеләр белән аралашкансыз, дип шелтәләп куйды.* М.Хәсәнов. *Хатны укыгач, Карәхмәт ярты ел эчендә беренче мәртәбә рәхәтләнеп, озак итеп, онытылып көлде дә: «Ну, Йосыф!» – дип, эченнән генә аны шелтәләп куйды.* З.Хөснияр

**Шелтәләп ташлау** Көтмәгәндә, кызулык белән шелтәләү. *Беркөнне ул эшкә юка киенеп чыккан Мөнирәне бик каты шелтәләп ташлады.* Г.Әпсәләмов. *Икеләнеп баруым өчен, үземне үзем шелтәләп ташладым.* Г.Бәширов

**Шелтәләп тору** Һәрвакыт, даими шелтәләү; әле, хәзерге моментта шелтәләү. *Барсак, кызлар Сәлимне шелтәләп торалар иде: – Ни эшкә шулай карга булып карылдарга икән?* Г.Бәширов. *[Әлфия ханым:] Нигә мине шелтәләп торырга тиешләр? Мин бит томана түгел, акылсыз хатын түгел.* Р.Батулла

**Шелтәли башлау** Шелтәләргә тотыну. *Шаһи карт, ай, яшьлек, юләрлек, нигә юк белән үзеңне харап итәргә дип, егетләрне шелтәли башлады.* Г.Ибраһимов. *Фёдор Степанович көтмәгәндә кулларын җәеп җибәрде дә Әсәдуллинны шелтәли башлады: – Их, Якуб Хисамович, карап торам-торам да аптырап калам.* С.Сабиров

**ШЕЛТӘЛЕ** *с.* Шелтә белдергән, шелтәләрдән торган. *Илһамиянең тавышындагы шелтәле шаянлык җиңелчә үпкәләү һәм назлану белән алмашынды.* Г.Әпсәләмов. *Үз чиратында кыз аңа шелтәле караш ташлады, әмма, ни гаҗәп, башка вакыттагыча тел озынайтып тормады.* А.Әхмәтгалиева

**ШЕМАЯ** *и. фар. к.* **майбалык**

**ШЕПКӘН** *и. бот.* Әвернәчәчәкләр семьялыгыннан аксыл сары яки алтын сары чәчәк ата, культуралаштырылган төрләре май алу өчен һәм терлек азыгы буларак игелә торган берьеллык үләнчел үсемлек; *русчасы*: **сурепица**. *Сары, ак ромашкалар, ипи чәчәкләре, шартлавыклар, шепкәннәр бергә-бергә җилдә рәхәт чайкалышып утыралар.* А.Гыйләҗев

**ШЕРЕ́НГА** *и. венг.* Бер-берсенә яны белән басып бер сафка тезелгән кешеләр рәте. *Ротный кече командирларны җыеп нидер аңлаткач, тегеләр, үз отделениеләрен танкодромга каратып, бер шеренгага тезделәр ---.* Р.Кәрами

**ШЕСТЕРНЯ** *и. рус* Механизмнарда хәрәкәтне күчерә торган тешле тәгәрмәч; йолдызча. *Йолдызча капкачын ачып карагач, аның коты алынды: конуссыман роликлы ике подшипник һәм олы шестерня бернәрсәгә яраксыз хәлгә килгән иде.* Н.Фәттах. --- *майланган частьларын җыя башлагач, Әлтафи бераз аптырап калды: тегеләй итеп тә, болай итеп тә карады, әмма дәү сәгатьнең нәкъ бер кушуч шестерняләры артып кала иде.* М.Мәһдиев

**ШЕФ** *и. фр.* **1.** 1) Кемгә яки нәрсәгә дә булса түләүсез даими ярдәм, булышуны рәсми рәвештә үз өстенә алган кеше яки учреждение. *Урак өстендә һәм бәрәңге алган чакта, шәһәрдән шефлар килгәч, кунак йортында хәтта утызар карават куялар.* В.Нуруллин. *Их, әрәмнәр генә иткәнсең! Җан кебек сәгать иде! Интернатның кырык еллыгына шефлар бүләк иткән иде.* М.Маликова

2) Кайбер илләрдә предприятие, учреждение, хәрби подразделение һ.б.ш. белән җитәкчелек итүче кеше. *– Ну-у, Галимов! Сезгә Америка ФБРында шеф булып кына эшлисе бар.* З.Зәйнуллин. *Полиция шефы үзенә 235 сумлык квитанция язган һәм аны икенче көнне үк түләгән.* Татарстан яшьләре

3) *сөйл.* Эш башында торучы кеше, башлык, җитәкче (үз кул астында эшләүче кешеләргә карата). *Миңа безнең шеф күптән түгел генә әйтте, әгәр дә син болай йөрсәң, урыныңнан да очарсың, диде.* Г.Камал. *Мин – «Киноплёнка» клубында директор урынбасары, ә ансамбльнең җитәкчесе Рифкать Гомәров – минем шеф.* А.Хәмзин

4) *сөйл.* Автобус йөртүче, таксист һ.б.ш. эштәге ир-атка мөрәҗәгать итү сүзе. *– Кая барыш, шеф? – дип сорый шофёр, кузгалып киткәч тә һәм бардачоктан яшел каплы «Шипка» сигаретын алып кабыза.* А.Тимергалин. *Габделнур, фәкать ир-атка гына мөрәҗәгать итүен сиздерү өчен, «син»гә басым ясады. – Шеф, син зерә алай тупас сөйләшәсең. Мин синнән стакан гына сорамакчы идем. Ярый, хуш...* Р.Кәрами

**2.** *с. мәгъ.* Кушма сүзләр составындагы икенче сүз аңлаткан һөнәр, эш буенча җитәкче; башлык вазифасын башкарган, өлкән, баш. *Шеф пешекче бик нык тырышкан – өстәлләрдә кыздырылган тавык, тәмле балык, лимон белән шпрот, --- алмалар һәм әфлисуннар да бар иде.* Р.Мостафин. *Әлеге гомумтөрки газет редакциясенә җитәкче итеп немец Винанде, төркестанчылар, азәрбайҗаннар Кырым һәм Идел буе татарларыннан берәр шеф мөхәррир кертелә.* Т.Насыйров

◊ **Шефка алу** Кемгә яки нәрсәгә дә булса түләүсез даими ярдәм итәргә, булышырга алыну. *Бераздан ул дәфтәрне ябып куйды һәм сүзен дәвам итте: Менә сезнең классыгыз колхоз бозауларын шефка алган, әйбәт кенә эшлисез дә икән.* Г.Рәхим. *Мәктәптә дирекция һәм укытучылар белән егетне шефка алу хакында сөйләште.* Ф.Яруллин

**ШЕФЛЫК** *и.* Шеф булу, шефка алу; кемгә яки нәрсәгә дә булса даими түләүсез ярдәм күрсәтү буенча иҗтимагый эшчәнлек. --- *уйлана торгач, Изаил Харисовичның электән үк килгән сәерлекләре искә төште: ул, мәсәлән, заводларга барырга яратмый, шефлык эшләренә катнашмаска тырыша иде.* М.Маликова. *Берсенең дә, төзелеш эшенә чыгып, бераз җилләнәсе килми. Шефлык та начар бара, колхоз-совхоз эшләрендә актив катнашмыйбыз.* Н.Хәсәнов

**ШЕШ** I *и.* 1) Организм тукымасы җилсенүдән эрен, үлек җыйналу сәбәпле барлыкка килеп кабарып торган авыртулы урын. *Хирург --- скальпелен спирт белән ышкып, шешне ярып җибәрде. Бер тәлинкәгә якын үлек акты.* Ф.Яруллин. *Тарасенконың бәхетенә, инфекция таралып өлгермәгән иде. Шешне ярып, бик җентекләп чистарттым.* М.Әмирханов // Гомумән, авыртулы төер. *Эчтә калган сүз шешкә әйләнә, имеш.* Мәкаль

2) *сөйл.* Сызлавык, чуан. *Шеш тишелүдән барлыкка килгән җөйләр тәнемдә хәзер дә бар әле.* Ә.Галиев. *Өстәвенә шул ук аягына зуп-зур шеш чыкты да шул тишелеп агып йөдәтте.* М.Хуҗин

3) Бәрелү-сугылудан кан оешып, яңа тукыма үсүдән кабарып торган урын. *Еш кына сәнгатькяр адәм баласына тиеш бәхеттән өлешсез кала, шуңа күрә сакаллы сабыйларның маңгаенда – шеш, күз төбендә фонарь күгәреп торыр, ә җаннарында – бетәшмәс яра...* А.Тимергалин. *Диана, калтырана-калтырана, баш артын тотып карады. Анда шактый зур булып шеш кабарып чыккан иде.* Ф.Тарханова // Калкулык, гомумән кабарып, очлаеп торган урын. *Шеш-шеш чыгып торган ташлы таулардан, әллә нинди тигезсез күперләрдән үтәргә туры килә.* Г.Тукай

◊ **Шеш өстенә шөш (чөш)** Начарлык өстенә начарлык өстәлү. **Шеш тишелү** Күңелгә җыелган нинди дә булса хис сыеша алмый ташып чыгу. *Әлегә Кәшшаф та, Әлтаф та дуслык чиген үтеп чыгарга кыймый. Шул ук вакытта күңелгә төйнәлгән бу шеш тишелмичә дә кала алмый. Ул инде тулган.* М.Әмирханов. **Шеш тулу** Нинди дә булса яман эшләр артык күпкә китеп, фаш ителер, чара күрелер вакыты җитү яки сабырлык бетү, түземлек төкәнү, соңгы чиккә җитү. *Әйе, халыкның күпчелеге тормыштан риза түгел. – Шеш тула да бер тишелә, – диде Шәрәфи, авыр сулап, – халык үз сүзен әйтми калмас.* Ә.Галиев. *– Сабыр гына шеш тулганны көтеп утырырга дисез инде, алайса. – Көтеп утырырга димим. Безгә хәзер үтә сак кына милли-мәдәни үсешнең, милли уянуның программасын эшләргә кирәк.* Р.Юныс

**ШЕШ** II *и.* **1.** 1) Ныклык өчен кибән үзәгенә кадап калдырыла яки һава кереп йөрсен өчен печән, тары яисә борчак чүмәләсе эченә куыш ясауда файдаланыла торган очлы башлы озын колга, туры казык. *Иртән торып тышка чыксам, агач башы шеш кебек.* Г.Тукай. *Их, әле бар: зур хуҗалыкның кибәннәрен куеп, Шеш кадагач, бастырык салып түбәсен очлыйсы.* Һ.Такташ

2) Ит, шашлык кебек нәрсәләрне кыздыру өчен махсус калын тимерчыбык. *Алар итне тимер шешкә кидереп, утта кыздырачаклар ---.* Н.Фәттах

**2.** *с. мәгъ.* Төз, туры. *Кыска койрык, шеш колак.* Табышмак. *Шеш аяклы, шеш мөгезле Болансы күп Алман-тау.* Н.Исәнбәт

**ШЕШӘ** *и. фар.* Сыекча салу өчен тар авызлы озынча пыяла, пластик һ.б. материалдан ясалган савыт. *Өстәл өстендә бер шкатулка, бер-ике ислемай шешәсе, пудра савыты.* Г.Камал. *Артур калкынды, үрелеп дару шешәсе алды, тиз генә микстура салып, Асяга бирде.* Х.Камалов

◊ **Шешәсе тулу** 1) *эвф.* Күз яше тулышу, еларга тору; 2) Күңел тулу. *Линүзә театрдан кайтып килә икән, элек тә зифа гәүдәсе тагын да югара төшкән, каратут йөзе сагышлы – «шешәсе тулган, бөкесе атылырга тора».* Р.Кәрами. **Шешә төбе ялау** 1) Кемгә дә булса буйсынып яшәү, ул кушканны үтәү; бик аз акча бәрабәренә хезмәт итү, ялчы булу. *Син бит минем шешә төбемне ялый торган адәм.* Г.Ибраһимов; 2) *к.* **шешә ялау**. --- *бусы --- алкашлыкта йөри. Бер кесәсендә шешә,*

*икенчесендә стакан була аның. Шешә төбе яларга яратучы үсмерләрне аулаграк аллеяга ияртеп китә дә --- бер стакан суррогат белән «сыйлый» үзләрен.* Ш.Маннур. **Шешә ялау** Эчү, эчәргә ярату, эчкечелек белән даими шөгыльләнү. *Гайфи абый да сирәкмирәк кирә башлады Баязит абыйларга. Андый көн бәйрәм була минем өчен. Шешә яламый, ичмасам.* А.Гыйләҗев. *Көрәшү теләге канында бар, сәләтен табигать биргән – ансыз да яши алмый, шешә ялаудан тыелырга да ихтыяр көче җитми иде.* Р.Кәрами

**ШЕШӘДӘШ** *и.* Бергә эчүче кеше, эчүчелек белән шөгыльләнүчеләрнең берсе. – --- *утка карап сүзсез генә уйланып утырганда, минем янга дустым Василий килеп керде... – Дустың түгел, шешәдәшең ул синең! – дип кычкырды ачу белән кызның анасы.* Ә.Сафиуллин. – *Өйләнергә кирәк сиңа, Сәйфи дус, өйләнергә кирәк, – Гайфи, стаканда калган аракысын йотып куйгач, тозлы кыяр кыерчыгын кетердәтә-кетердәтә, кулын шешәдәшенең иңнәренә салды.* Ф.Имамов

**ШЕШӘК** *с. диал.* Икенче яшендәге, икенче яше белән бара торган, икенче яшенә чыккан. *Шешәк сарык. Шешәк кәҗә*

**ШЕШӘЛЕ** *с.* 1) Шешәгә тутырылган, шешәдә сатыла торган. *Шешәле сөт белән бер булка алам да шулар белән тамакны үткәрәм.* М.Маликова. *Тәмлетәмле җимешләр, матур шешәле соклар, төрледән-төрле шоколадлар, бананнар, апельсиннар куйды.* Ф.Яруллин

2) Шешәсе булган, шешә белән тәэмин ителгән. *Сарык бәрәннәре Сәгыйдә кулындагы шешәле имезлектән сөт тә имәргә сорамыйлар, сикерешепшаярышып, уйнап та китәргә тормыйлар.* Р.Кәрами

**ШЕШЕК** I *и. к.* **шеш** I (*1 мәгъ.*). – *Ах, Нуриҗан, миңа шешек чыкты... – Кайда? – Менә шунда, – дип, кыз, оялып, түшенә күрсәтте.* З.Мурсиев. *Тамыр саркындысын шулай ук ревматизм, төче авыруы, тимрәү булганда, шешек чыкканда кулланалар.* Сөембикә

◊ **Шешеге тулу** *к.* **шеш тулу**. **Шешеге тулышу** *к.* **шеш тулу**

**ШЕШЕК** II *с. к.* **шешенке**. *Нинди закон чыгарыйм бу алкашларга, Вавилонда сыра түгел, су да җитми Кызыл танау, шешек йөз, беткән башларга.* Г.Афзал. *Булат әмир, ашыкмыйча, Бату ханга күз йөгертеп чыкты. Әзмәвердәй гәүдә. --- Болгарларга охшатып калдырган пөхтә сакал-мыек. Шешек күз кабагы.* В.Имамов

**ШЕШЕМСЕРӘҮ** *ф. к.* **шешенкерәү**. *[Касыймның] йөзе борчулы, күз төпләре шешемсерәгән. Бөтен килешкилбәте, кыяфәте белән кайгы-хәсрәт кичергән кешене хәтерләтә.* Г.Галиева. *[Сәлихҗан абзыйның] иртән торуга, битләре шешемсерәгән, күз кабаклары салынган.* Р.Төхфәтуллин

**Шешемсерәп китү** Бераз шешемсерәү. *Егылганда, бәрелгәндә, гадәттә, тәннең йомшак тукымалары зарарлана, шул ук вакытта еш кына вак кан тамырлары да өзелә, бу урын шешемсерәп китә, кан сава һәм тән кара янып чыга.* Йорт эшләре

**Шешемсерәп тору** Әле, хәзер шешемсерәгән булу

**ШЕШЕНКЕ** *с.* Җиңелчә шешкән, шешенеп, кабарып, күпереп торган. *Калын пыялалы күзлек кигән шешенке битле хатын егетнең студентлык билетын әйләндерә-әйләндерә карады ---.* А.Гыйләҗев. – *Син мине эзләрсең, табарсың, – дип, дога урынына пышылдады аның шешенке иреннәре.* М.Маликова

**ШЕШЕНКЕЛӘНҮ** *ф.* Шешенке хәлгә килү, җиңелчә шешенү, күперү, кабару. *Иреннәре, турсаюдан булса кирәк, умарта корты чаккандай, шешенкеләнеп күренде.* Б.Камалов

**Шешенкеләнә бару** Акрынлап, азазлап шешекләнүе арту

**Шешенкеләнә төшү** Бераз шешенкеләнү; тагын да шешенкеләнү

**Шешенкеләнеп китү** Сизелерлек, күзгә күренеп шешенкеләнү. *Айгөл килеп керде. Битләреннән яшь ага, елаудан күзләре кызарып, йөзе шешенкеләнеп киткән.* Ф.Сафин

**Шешенкеләнеп тору** Әле, хәзер шешенкеләнгән хәлдә булу. *Вил Садриевич үз бүлмәсендә бухгалтер керткән кәгазьләрне карап утыра иде. Күз төпләре шешенкеләнеп тора, йөзенә саргылт тут йөгергән.* Х.Камалов

**ШЕШЕНКЕЛЕК** *и.* Шешенке булу хәле. *Командир дигәннәре инде торган, ләкин юынырга өлгермәгән иде булса кирәк: чәчләре тузгыган, күз кабакларының йокы шешенкелегә бетмәгән иде.* В.Нуруллин. *Чәйдәге танин дип аталган матдә лимфа агышын тизләтә, шул рәвешле күз төбендәге шешенкелек тә бик тиз юкка чыга.* Сөембикә

**ШЕШЕНКЕРӘҮ** *ф.* Бераз гына шешенү, шешенгән кебек булып китү, җилсенү. *Мин шешенкерәгән имән бармагымны стена салкынынарак сузам.* Г.Бәширов. *Озакламый ишектә Касыйм да пәйда булды. Йөзе борчулы, күз төпләре шешенкерәгән.* Г.Галиева

**Шешенкерәп китү** Сизелерлек, күзгә күренеп шешенкерәү. --- *аның ярасы сап-сары булып үлекләгән, ә бөтен уч төбе кызарып, шешенкерәп киткән иде.* Ш.Маннур. *Яңа гына уянган апасының йөзе алланып, шешенкерәп киткән.* Р.Вәлиев

**Шешенкерәп тору** Әле, хәзер шешенкерәгән хәлдә булу

**Шешенкери төшү** Бераз шешенкерәү; тагын да шешенкерәү. *Ленинның арзанлы гипстан койган һәм кат-кат ак буяу белән буяганга күз төпләре чак кына шешенкери төшкән бюсты янына утырып, Азат мәсьәләне кабыргасы белән куя ---.* А.Тимергалин. *Шешенкери төшкән күз кабаклары арасында тычкан балалары кебек йөгерешкән ягымлы көрән күзләре генә «мин – Максимов» диләр.* Г.Шәрәфетдинов

**ШЕШЕНҮ** *ф.* 1) Тәнгә сыеклык таралу сәбәпле, тән тукымасының аерым бер урыны кабару. *Хәсәнә абыстай, кызына күрсәтмәс өчен, елаудан шешенгән күзләрен яулык чите белән каплап, тышка чыкты.* С.Поварисов. – *Кер, ят! Йокламаган кыз-катынның күз кабаклары шешенә, бит тиресе сәлперәя, ә син миңа матур килеш кирәк.* Н.Гыйматдинова

2) Тоташ шешеп чыгу, кабарып чыгу. *Битен-башын черки талаган, шешенеп бер атна өендә ятты.* М.Мәһдиев. *Кан тамырларының тараюы сәбәпле, аяклары шешенә аның.* К.Кәримов

3) *мед.* Организмда матдәләр алмашы бозылу яки башка сәбәптән сыеклык тән күзәнәкләренә таралу, ялкынсынып шешү. *Мин әйтәм: «Баш мие шешми микән?» дим. Профессор: «Әйе, – ди, – үпкәсе дә шешенә», – ди.* Р.Нуруллина

4) Ачлыктан, организмга азык җитмәүдән тән беркадәр тулышу. *Кеше ачлыктан шешенә икән, күз төпләре бүртенә, битләр калыная, ашамагач, каян килә инде бу? Халык моны аңламый, әмма шешенеп үлә тора.* М.Мәһдиев. *Ачыгабыз, шешенәбез, кышның үзәккә үткеч суыклары җанга тия.* Р.Кәрами

**Шешенә башлау** Шешенергә тотыну. *Кырык өчнең апрелендә ачтан шешенә башладык.* М.Мәһдиев. *Җәяүләп күп чакрымнар узудан Рәшитнең*

*кечкенә ялан аяклары шешенә башладылар.* З.Зәйнуллин

**Шешенә төшү** Бераз шешенү; тагын да шешенү. *Тонык яктыда аның әзрәк шешенә төшкән шадра йөзе шактый кырыс, хәтта усал күренде.* Г.Әпсәләмов. *Андагы салам, буш капчыклар өстенә елаудан күзләре шешенә төшкән алты хатын утырган иде.* З.Зәйнуллин

**Шешенеп бетү** Тәмам, бик нык шешенү. *Баш-аягы исән калуына сөенергә дә белмичә, Нәҗип өенә кайтты; елап, шешенеп беткән Наилә аның күкрәгенә капланып бик озак үкседе.* А.Гыйләҗев. *Кәбир звонок төймәсенә баскач, эчүдән шешенеп беткән Рамилә, ишекне ачып, йокы бүлмәсендәге караватка барып ауды.* З.Мәхмүди

**Шешенеп китү** Кинәт шешенү. *Аның гәүдәсе дә шешенеп киткән, ул, караватына сыя алмыйча, кисеп аударган имән кебек, авып ята.* Ф.Бәйрәмова. *Йөзе сулып калган балакайның, төннәр буе мендәрен кочаклап елап чыккан, ахры, күзләре кызарып, шешенеп киткән.* И.Сираҗи

**Шешенеп тору** Хәзерге вакытта шешенгән хәлдә булу. *Аның күзләре кызарган, битләре ничектер шешенеп тора иде.* Ж.Рәхимов. *Аның сулган йөзендә гаҗизлек галәмәтләре ярылып ята, ә сул күзе тирәсе яшелле-мөшелле булып шешенеп тора иде.* М.Маликова

**Шешенеп чыгу** Нинди дә булса сәбәптән нык, тоташ шешенү. *Разиянең аяклары, куллары, тәне шешенеп чыккан.* И.Гази

**ШЕШМӘ** *с. диал. к.* **шешенке**. *Өстәл артындагысы чәче коела башлаган, урта яшьләрдә, кызыл шешмә битле, җилкәсен чыгара төшкән, ул каядыр ашыккан, бераз каударланган кебек, һаман аяк өстендә килеш, куллары белән өстәлдәге нindидер кәгазьләрне капшый ---.* Н.Исәнбәт. *Карыйм, бер дә урыс егетенә охшамаган бу. Табаграк битле, шешмә күз кабаклы, йөзе дә бераз саргылтрак.* Г.Гомәр

**ШЕШМӘК** *и.* **1.** *к.* **шеш** I (*1 мәгъ.*). *Инде аяк йөзләрендәге, күз төпләрендәге шешмәкләр бетеп бара иде.* М.Мәһдиев

**2.** *с. мәгъ. диал. к.* **шешенке**. *Габбас мулланың, --- Сөләйман хәзрәттән аермалы буларак, сумаладай кара, шешмәк кабаклы кысыграк күзләре тыныч, гамьсез дә кебек иде.* Г.Ахунов

**ШЕШМӘКЛӘНҮ** *ф. диал. к.* **шешенкеләнү**. *Моңарчы председатель безнең күз алдында йончылган соры йөзле, йокысызлыктан күз кабаклары шешмәкләнгән һәм арып хәлдән тайган бер кеше булып килеп баса иде.* Г.Ахунов. *Ул, чыннан да, сулган ап-ак йөзле, күз төпләре шешмәкләнеп, күгәреп тора, озын гәүдәсе җайсыз сыгылып килгән кебек иде.* Ф.Бәйрәмова

**Шешмәкләнеп китү** *к.* **шешенкеләнеп китү**. *Фәһим абзый, кесәсеннән дүрткә бөкләнгән чиста кульяулыгын сабыр гына чыгарып, черем итеп алган чакта шешмәкләнебрәк киткән күз кабакларын сөртте ---.* Г.Ахунов

**Шешмәкләнеп тору** *к.* **шешенкеләнеп тору**. *--- бик юаш кыяфәтле бу кешенең --- ап-ак битләре шешмәкләнеп тора, колаклары кечкенә, --- уң күз кабагы һәрвакыт асылыныбрак тора.* Ф.Садриев

**ШЕШҮ** *ф.* 1) Кабарып чыгу, күперү, тулышу. *--- ачулары килгән кортлар аның саен зәһәрләнебрәк чактылар. Хәлим картның күзгә күренеп битләре --- шеште.* Ф.Яруллин // Эренле шеш барлыкка килү. *Ярама пычрак кергән, ахры, шеште, йөрәккә төшеп сызлый.* Г.Тавлин. *Рузия бертуктаусыз сөйләнә: – Бармагым шешкән ие дә хәзер тишелде инде.* М.Яһудин

2) Организмда нинди дә булса берәр әгъза ялкынсыну. *Мине күрүгә, сыңар күз кабагын күтәрә төшеп: – Булмый, малай, барып булмый, гландаларым шешкән, – диде. Рамилнең шул булыр инде: безнең сыман тамак шеште димәс, гланда дияр.* Н.Әхмәдиев. *Кәбир мулла көч-хәл белән генә йөри иде. Бавыры шешкән, ахрысы.* З.Мәхмүди. *Тик син хәзергә сөйләшмә, яме, акыллым, үпкәң нык шешкән, көч килмәсен.* З.Мурсиев

3) *к.* **шешенү**. *– Күз кабакларым гына шешкән бугай, – дип сөенде ул. Аннары, шик калмасын өчен, шешкән күз кабагын тагын бер тапкыр югары күтәрде һәм яңадан айны күрде.* Г.Әпсәләмов. *Төннәр буе елап, күзләрем шеште.* М.Маликова

**Шешә бару** Акрынлап, аз-азлап шеше арту. *Ә Җамалетдиновның аягы һаман да ныграк шешә барган.* Р.Мостафин. *Өйләнешкәннән соң, гаилә тәнендә сыткылар гына булып күренгән-авырткан җирләр зур чуаннар булып шешә барып, бер-бер артлы шартлап тишелә, ага башладылар.* З.Дәүләтов

**Шешә башлау** Шешергә тотыну. *Ул --- эчке күлмәгем аша гына күкрәгемне тыңлап карады, --- шуннан соң гына әниемә борылып әйтте, салкын тиюдән туташның үпкәсе шешә башлаган, диде.* Ә.Еники. *Юматшаның хәле көннән-көн начарлана бара. Бик хәтәр рәвештә мие шешә башлаган.* Г.Әпсәләмов

**Шешә төшү** Бераз шешү; тагын да шешү. *Хатын бик карт та түгел, бөркәнчек кигәнгә генә әби булып күренә, җитмәсә, аяклары шешә төшкән, чатанлый.* Г.Әпсәләмов. *Күзләре һәм авыз-борын тирәсе тагын да шешә төшкән.* А.Шамов

**Шешеп китү** Кинәт шешкән хәлгә килү. *Чыннан да, аның иңбаш сөяге каймыккан, шешеп киткән, хәзер кулын муенына асып йөри.* Л.Ихсанова. *Килендәшемнең гөбе кебек шешеп китә аяклары, авыртуы йөрәккә төшә, ди торган иде, мескенкәем.* Г.Якупова

**Шешеп тору** Әле, хәзерге вакытта шешкән хәлдә булу. *Рәхәтләнеп, авыз тутырып ашарга тешләрем ирек бирмиләр. Сул як яңагым гел шешеп тора диярлек.* Г.Кутуй. *Ә сәламәт кешенең, гадәттә, шөпшә тешләгән урыны кызарып, шешеп тора да бераздан бетә.* Татарстан яшьләре

**Шешеп чыгу** Кинәт шешү; нык, тоташ шешү. *Болхонский авырып урынга егылды, аның теге вакытта өшегән аяк-куллары зәңгәрләнеп шешеп чыкты һәм чери башлады.* Ф.Бәйрәмова. *Бер кичне Нуриянең температурасы утыз тугызга күтәрелде, колаклары чәнчешеп, муенындагы бизләре шешеп чыкты.* Р.Хәбибуллина

**ШИБЛЕТ** *и. сөйл. к.* **штиблет**. *Аның өстәл өстендә каләмнәр, --- иске китаплар, шиблет янында бер иске читекнең балтыры күренеп тора иде.* Г.Исхакый. *Өстенә җөббә, аягына шиблет, башына каракүл бүрек кигән --- Казан шәкерте Зәки Гайфи тәкәллеф белән генә атлап барды.* Г.Ибраһимов

**ШИВӘ** *и. фар.* Диалект. *Төрки телләрнең һәрберсе тагы әллә ничәшәр аерым шиваләргә, аерым сөйләшләргә бүленеп беткән.* Г.Алпаров. *Дабруҗа татар шивәсенә генә хас тел үзенчәлекләре, халык авыз иҗаты үрнәкләре белән очрашу да күңелне сөендерә.* Т.Әйди

**ШИВӘЧЕЛЕК** *и.* Диалект, җирле сөйләш үзенчәлекләрен чагылдыру, диалектизмнар белән артык мавыгу күренеше. *Бу мисаллар, беренчедән, ныклы эшләнгән әдәби кануныбыз булмауны икърар итсәләр, икенчедән, шивәчелек, аерым бер район йогынтысына ияргәнлекне күрсәтәләр.* Т.Гыйззәт. *Боларда саф шивәчелек элементлары (әйтик,*

*Насыйрида – мишәр, Камалда – Казан, Тукайда – Казан, типтәр, мишәр, казакъ) бик, бик аз һәм булганнары да һич тә аларның әдәби тел нигезен хасил итми ---.* Татар әдәби теле тарихы

**ШИГА** *и. гар.* 1) *к.* **шигый**. *Шигалар чыкты, голәма арасында бидгать күбәйде, әллә нинди китаплар яза башладылар.* Г.Исхакый

2) *к.* **шигыйлык** (*1 мәгъ.*). *Шига тарафдары*

**ШИГАРЬ** *и. гар.* 1) Сәяси, дини һ.б. өлкәләрдә кулланылган, төп идеяне яки таләпне, бурычны белдерә торган кыска мөрәҗәгать; кыска өндәмә; лозунг. *Интернационализм гөрләп чәчәк аткан, бөтен милләтләр бертигез, җәмгыятьтә бары бер генә тел – урыс теле генә калачак дигән шигарьләр чәчәк аткан чорда өйләнеште алар.* Г.Бәйрәмова. *«Бәя килешү буенча!» дигән игълан яздыртып куйды. Гомере буе шигарьләр, транспорантлар, афишалар, игъланнар язган элекке клуб мөдире өчен бу чүп кенә инде.* З.Мәхмүди

2) Киләчәктә ирешү, булдыру өчен билгеләнгән бурыч; максат. *Без, гомумхалыкның уртак шигаре булган бердәм хәрәкәт, юктан бар итү, гомуми иҗат энтузиазмы, кешеләр һәм халыклар белән кулга-кул тотынып, яңа дөнья төзү юнәлешендә яшибез.* Ф.Хөсни

**ШИГӘЮ** *ф.* Сагаю, игътибарны арттыру, саклык-сизгерлек тойгысын көчәйтү. *Ул, Рәшат тәмам кызып җитәр дә бүлмәдә булган кешеләрнең һәммәсен тукмап ташлар, дип шигәя иде.* А.Гыйләҗев. *Тавис ишегалды белән веранда арасында ду килеп йөри, кердәчыга, әнисе, шигәеп, аның җиңенә ябыша: – Улым, дим, улым! Чү, салгансың икән – ят та йокла, ник алай адәм мәсхәрәсе ясыйсың?* М.Мәһдиев

**Шигәя башлау** Шигәю барлыкка килү. *Берничә көн шулай бергә мәктәптә кич уздыргач, Нәркис аннан шигәя башлады: дипломсыз авыл егете, мәктәпнең хуҗалык мөдире – ат җигеп йөрүче Заһир «Декамерон»ны да, --- Бомаршены да белә икән.* М.Мәһдиев. *Бибинур башта көлемсерәп кенә йөргән иде, хәзер шигәя үк башлады: берәр ягын ошатмыймы ире аның?* Сөембикә

**Шигәя калу** *к.* **шигәеп калу**. *Арыслан, бу шушында ук бөгәрләнеп төшмәгәе дип, берхәтле шигәя калды һәм стакан белән сөтле кофе китерде.* Ш.Маннур. *Хариска үзенә ышанган кебек ышанса да, эшләр болайга киткәч, Нурислам бер мәлгә үзе дә шигәя калды ---.* М.Хафизов

**Шигәя төшү** Бераз шигәю; тагын да шигәю. *Миендә чәбәләнгән уйларның очын эзләгәндәй ул нигәдер шигәя төшеп, караңгылыкка текәлеп торды.* А.Вергазов

**Шигәеп йөрү** Һәрвакыт шигәю. *Мусадан куркып, шигәеп йөргән Шәфи Алмаз аңа кинәт кенә ышана башлады.* Ш.Маннур

**Шигәеп калу** Кинәт шигәю; берәр сәбәптән шигәю. *Диас: «Сабир абый! Мин бүген сезгә (Галәү белән Зохага борылып) һәм сезгә ике яңалык әйтәм». Барысы да шигәеп калалар.* М.Мәһдиев

**ШИГӘЮЛЕ** *с.* Сагаюлы, шикләнүле, шөбһәле; саклыкны, шиклелекне белдерә торган. *Шигәюле, ышанмаучан карашлар, сабыйларның авырулары --- шактый нәрсәләр баштан кичте.* Р.Төхфәтуллин. *--- без ни өчен хәзер дә, нинди генә эшләргә тотынсак та, иң башта куркулы, шигәюле күз белән тирәягыбызга карыйбыз.* Фәнни Татарстан

**ШИ́ГЪРӘН** *рәв. гар. иск.* Тезмә юллар белән, шигырь итеп, шигырь үлчәвенә салып. *Фикерне шигърән әйтеп бирә алу сәләте*

**ШИГЪРИ** *с. гар.* 1) Шигырь формасында язылган, тезмә. *– Чибәркәем, борма инде йөзләреңне читкә, – диде ир шигъри юллар белән диярлек.* И.Шиһапов. *Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, Урта гасырлар дәверендә шигъри әсәрләр уен коралларына кушылып, мәкам белән көйләп башкарылганнар.* Г.Макаров

2) Шигырьгә хас, шигырьдәге кебек, поэтик. *Муса балачактан белә: болытлар алар – җил, кояш, таң, чәчәк, сандугач кебек, шагыйрьләрнең иң яраткан шигъри образлары, бизәкләре ---.* Г.Әпсәләмов. *«Акай» ул, һичшиксез, ак ай дигән шигъри образдан алынган.* Н.Әхмәдиев

3) Искиткеч, гаҗәеп дәрәҗәдә гүзәл, илаһи. *Харисов – Агыйдел буйларының сихри, шигъри матурлыгын, анда сайраган сандугачларның моңын йөрәгенә алып, күңеленә сеңдереп үскән табигать баласы.* С.Поварисов. *Нәрсә турында иде соң шигырьләр? Яшәү, үлем, кайгы-хәсрәт, кичеккән мәхәббәт. Әле дөньяны яңа гына таный, аңлый башлаган Рузалиянең шундый тирән уйлар, шигъри хисләр эчендә бәргәләнүе Әнсарның исен алды.* Х.Ибраһим

**ШИГЪРИЛЕК** *и. к.* **шигърият** (*2 мәгъ.*). *Бөтен бакча, бөтен һава, бөтен көн, бөтен дөнья бертөрле әйтеп аңлатып булмый торган ләтыйф шигърият (гүзәл шигърилек, матурлык) белән тулган иде.* Г.Рәхим. *Урман каравылчысы – җырчы ир үзе язган «Урман вальсы»н җырлап күрсәтте. Йөзендә, кыяфәтендә затлы нәфислек, мөлаем шигърилек, эчке яктыру бар...* Ш.Галиев

**ШИГЪРИЯТ** *и. гар.* 1) Шигырь иҗат итү сәнгате, поэзия. *Халыкның, бигрәк тә яшьләрнең, әдәбиятка, аеруча шигъриятькә тартылган, поэтик сүзнең дөньяны яхшыга үзгәртә алу көченә ихлас ышанган чагы.* Р.Фәйзуллин. *Мәрҗәнә --- Көнбатышның зирәк китапларын укыса, Көнчыгышның шигъриятенә гашыйк.* А.Нәҗми

2) Искитәрлек гүзәллек, илаһи матурлык. *Табигать миләшне, усаклар сарылыгының шигъриятен күрсәтер өчен, алар белән бер үк вакытта кызарткан.* М.Мәһдиев. *Басма өстендә кызларның --- кер юулары, каз өмәләрендә --- көянтәләренә каз элеп --- елга буена барулар – --- халкыбызның эшне матур итеп эшли --- белүен күрсәтә. Гөлзада шушы күренешләрдә тормышыбызның шигъриятен ача алды.* Ф.Яруллин

**ШИГЪРИЯТЛЕ** *с. кит. к.* **шигъри** (*3 мәгъ.*). *Моннан ике ел чамасы элек, май кичендә танышкан идек. Язын. Иң шигъриятле вакытта.* А.Гыйләҗев. *Бу үзәк өзгеч шигъриятле моң башта бик кыюсыз гына яңгырады.* М.Хәсәнов

**ШИГЪРИЯТЛЕЛЕК** *и. кит.* Шигъриятле булу, шигъри булу. *Шигъриятлелек кеше гүзәллеге белән бәйле. Ул бер шигырь юлларына гына хас сыйфат түгел. Музыканы, скульптураны, графиканы, архитектураны да кеше күңеленә тоташтыручы, сәнгать итүче ул – шигъриятлелек.* Казан утлары. *XVIII–XIX гасырларда Казан патшабикәсенең гүзәл образы үзенең аеруча шигъриятлелеге, серлелеге һәм шәфкатьлелеге белән рус шагыйрьләре, язучылары, композиторларының игътибарын өзлексез җәлеп итеп тора.* Сөембикә

**ШИГЫЙ** *и. гар.* Ислам динендә шигыйлык тармагын тоткан кеше. *Шигыйлар пәйгамбәр итеп Галине таныйлар.* Г.Исхакый. *Сөнниләр һәм шигыйлар арасында тагын кайбер дини, хокук мәсьәләләрен хәл итүдә, дини бәйрәмнәрне үткәрү, намаз уку һәм ислам диненең кайбер йолаларын үтәүдә аерымлыклар яши.* Р.Фәхретдинов

**ШИГЫЙЛЫК** *и. дини* 1) Ислам диненең Мөхәммәд пәйгамбәрдән соң

хәлифәлек хәзрәте Галинең һәм аның нәсел дәвамчыларының гына хакы дип кабул ителгән юнәлеше. *Сөякләре череп бетеп көл булган рәвафизлар берлән тартышыр өчен күптән сәяси кыйммәте беткән шигыйлык, могтәзиләлек кебек исламның сәяси агымнары берлән кычкырышыр өчен тырмашалар, маташалар.* Г.Исхакый

2) Шигый булу. *Кемнеңдер шигыйлыгына шикләнеп карау*

**ШИГЫРЬ** *и. гар.* 1) Ритмга салынган рифмалы юллардан гыйбарәт текст. *--- шигърияттә хәзер силлабик-көйләм шигыреннән тоник шигырь төзелешенә, интонацион сөйләм шигыренә күчү көннән-көн ачыграк сизелә бара.* М.Шабаев. *Әдипнең «Фәрхи» поэмасы шактый вакыт аралыгында язылганга охшый. Авторның ике төрле шигырь үлчәме куллануы да (унберәр иҗекле икеюллык һәм сигезәр иҗекле дүртьюллык) шуны күрсәтә.* Ә.Закирҗанов

2) Шул формада иҗат ителгән әдәби әсәр төре, тезмә әсәр; *киресе*: **проза**. *Шигырьдә ритмик системаларның бер-берсен алмаштыруының сәбәпләре әле безнең шигырь теоретикларыбыз тарафыннан бик гомуми характерда гына өйрәнелгән.* Г.Нигъмәти

3) Кечкенә күләмле тезмә әсәр. *Шәйхи Маннур татар поэзиясендә үзенең күп кенә поэмалары һәм лирик шигырьләре белән күренекле урын алды.* М.Җәлил. *Мәхәббәт турында шигырь сөйләргә аның ни хакы бар?* М.Мәһдиев

4) *к.* **шигърият** (*2 мәгъ.*). *Зәңгәр күзләреннән шигырь сибеп, Көлеп тора минем фәрештәм. Бер мин генә түгел, аны күреп, Җиһан сәгадәткә ирешкән.* Ш.Бабич

5) *күч.* Җыр. *Барча кошның да үзенчә сайравы бар, шигъре бар.* Г.Тукай

**ШИГЫРЬЛЕК** *и.* **1.** Шигырь булу, шигырь сыйфатларына ия булу. *Шигыренең әүвәлге бүлеге мәгънә җәһәтеннән дөрес түгел. Шигырьлеге дә бик шөбһәледер ---.* Г.Исхакый. *Шигырьнең шигырьлеге көйгә китерүдә түгел, ә әйтергә телгән идеяңне матур, җанлы охшатулар, җанлы сурәтләр, конкрет җанлы картиналар аркылы, күңелгә үтәрлек бер аң һәм караш тудырырлык итеп бирүдә.* М.Җәлил

**2.** *рәв. мәгъ.* Шигырьгә җитәрлек, шигырьгә сыярлык дәрәҗәдә, шигырьләр язарлык итеп. *Сине ул тау [Кинә тавы] ничә шигырьлек хисләндерде әле?* Н.Гыйматдинова

**3.** *с. мәгъ.* Шигырьгә җитәрлек, шигырь язарлык. *Кемгә килер, кемгә килмәс... Көн дә килмәс... килсә дә. Ничә шигырьлек дөнья бу, Ничә җырлык гомерләр!* Р.Миңнуллин

**ШИГЫРЬЧЕ** *и. ирон.* Шигырь язучы; шагыйрь кисәге. *Гомумән, шигырь кул белән эшләнәме, языламы? Бөекләр генә түгел, гади шагыйрьләр дә (шагыйрьләр – шигырьчеләр түгел) кул белән язмыйлар, йөрәк яки акыл белән язалар.* Н.Нәҗми. *Сәхнәдә чын шигърият бетеп бара. Эстраданы арзанлы җыр текстлары күмеп китте, үзешчән шигырьчеләр басып алды.* Р.Миңнуллин

**ШИ́ЗИК** *и. рус сөйл. к.* **шизофреник** I. *Хат иясе кайчак шизик «даһи» бер тинтәк була.* Р.Фәйзуллин. *Шизиклар куркыныч түгел, бу мәсьәләдә аларның чыгыш ясавын безнең тегермәнгә су коюю, дип уйлады ул.* Р.Зәйдулла

**ШИЗОФРЕ́НИК** I *и. рус* Шизофрения белән авыручы кеше. *Шизофреник – дөрес фикерләү сәләтен югалткан, башында буталчыклык хөкем сөргән, тормышында барыр юлыннан адашкан кеше.* Р.Гарифуллин

**ШИЗОФРЕ́НИК** II *с.* Шизофрения авыруы белән бәйле, шул авыру аркасында барлыкка килгән. *– Мин медицина фәннәре кандидаты Дамир Динмөхәммәтов, шушы матур учреждениенең шизофреник авыруларны дәвалау бүлеге мөдире булам, – диде дә көлеп тә җибәрде.* А.Хәсәнов

**ШИЗОФРЕНИ́Я** *и. гр.* Психик процессларның үзара бәйләнеше бозылу һәм аң эшчәнлегенә зарар килү белән характерлана торган психик авыру. *Җиңел формадагы шизофрения, һәрхәлдә, шыр тилегә калып, акылдан тәмам язу түгел.* А.Хәсәнов. *Шизофрениянең агрессив булмаган, әмма медицинада «җиңел» дип бәяләнсә дә, тормышта бигүк җиңел булмаган формасы белән чирли милләттәшебез.* А.Хәлим

**ШИ-И** *иярт.* 1) Нәрсә дә булса зур тизлек белән һава ярып, сызгыртып үтеп киткәндә барлыкка килгән тавышны белдерә. *Ниндидер вак кошлар баш өстеннән атылып узып китәләр дә, һава ши-и итеп кала.* И.Гази

2) Зур тизлек белән хәрәкәт итү рәвешен белдерә

**ШИК** *и. гар.* 1) Кемгә дә булса ышанмау хисе; тәшвиш, шөбһә. *Дудин --- урман эченә кереп китте. Галим аның артыннан карап калды. Шунда аның күңелендә шик туды: бәлки, Дудинны түгел, башка берәр кешене өлкән итеп билгеләргә кирәк булгандыр.* Г.Әпсәләмов. *Хатын-кыз кайда да хатын-кыз булып кала инде, дип көлемсерәде эчтән генә Рәуф, суга батып барганда да чәчен төзәтер, иренен буяр. Шул ук вакытта күңеленә кереп оялаган шиге арта төште: шпион!* Ә.Эминев

2) Нәрсәнең дә булса дөреслегенә яки үтәләчәгенә, фикернең чынбарлыкка туры килүенә тулы ышаныч булмау. *Ну минем менә нәрсәдә шигем бар: бу кәгазь идарәдәге төп кенәгәгә, хисапчы кенәгәсенә теркәлде микән соң? Теркәлмәгәндер күк тоела миңа.* В.Нуруллин. *Әмма бер шигем бар – әгәр дә югарыда әйтелгән шөгыльләрнең барысы да тулаүлегә әйләнеп бетсә, безнең шулай ук бер эшебез дә барып чыкмаячак.* Р.Миңнуллин

3) Икеләнү, тәрәтдет. *Инде үзенең җиңеп чыгуына Зәйнинең шиге калмады.* З.Зәйнуллин. *Аннары без, күңелендә шик калмасын дип, ул карточкаларны конверты, хаты белән шундук тикшерүчегә илтеп тапшырдык.* С.Сабиров

4) Эчтән күңелне тырнап торган тынычсызлык; курку, шикләнү, шом. *Ул үз өендә асылынып үлде. Фаҗига бит. Нинди? Әлеге дә баягы шул халык каргышы түгелме икән дигән шик бар.* Г.Әпсәләмов. *– Кем? – Граф юкка сорамый. Аның күңеленә шик кереп оялаган иде инде.* Г.Гыйльманов. *Хикәяче, тавышына мөмкин чаклы ваемсызлык, битарафлык төсмере бирергә тырышып, өстәп куйды: – Чынында ышану-ышанмау сезнең ихтыярда. Тик минем тагын бер шигем бар.* Т.Галиуллин

◊ **Шик астына алу** 1) Ышанмау, шикләнеп карау. *Иң элек мин татар әдәбиятында поэзия бүтән төрләрдән, аерым алганда, прозадан өстенрәк тора дигән мәгънәдәге раславыгызны шик астына алыр идем.* Р.Фәйзуллин; 2) *юр.* Беренчел тикшеренүләргә нигезләнеп, расланмаган көенчә гаепләү. *Татарстан Республикасы буенча әлеге җинаятьне кылуда шик астына алып, пенсионерларның улын – 33 яшьлек Андрей Бареевны эзләүгә игълан итте.* Р.Әхмәтвәлиева. *--- әгәр әллә нинди контраларны яклап йөрисез икән, сезне алар белән бәйләнештә торуда шик астына алу – үзеннән-үзе килеп чыга торган гамәл.* З.Мурсиев. **Шик астындагы** 1) Ышанычсыз. *[Якуб Гафияткә:] Рәхмәт, син үзең дә шик астындагы кеше.* И.Гази; 2) *юр.* Расланмаган

көенчә җинаять эшендә гаепле дип уйланган. *Шик астындагы кешене Чуйков урамында урнашкан вакытлыча яши торган фатирында кулга алалар, ул анда, күпсанлы кредитлардан качып, әти-әнисе белән яшәгән.* Татарстан яшьләре. **Шиккә калу** 1) Элекке ышаныч бетү, шикләнү хисе уяну. *Тыштан тегеләргә бик теләп хезмәт итеп йөргән атлы булган Степан Петрович. --- һәм, билгеле инде, моның составлары «нигәдер» гел безнекеләр кулына эләгә башлаган. Шуннан аклар шиккә калган. Степан Петровичны, кулга алып, Алмазга озатканнар.* В.Нуруллин. *Олаучы капка төбендә бозауны алып чыгалар дип көтә иде. Бик озаклагач, шиккә калды. Кирам, киткәндә, капканы әллә ничек хәйләле итеп бикләп мәшәләнгән иде.* Ф.Садриев; 2) Куркып, шүрләп калу, шомлана башлау. *Хәзрәтнең шушы сүзләреннән соң теге гуаһларның берничәсе шиккә калган сымак булдылар.* М.Гафури. --- *телевидение, радио, газета-журналлар ярдәмендә халыкны чирләр белән куркыту, даруларны киң пропагандалау бара. Бу, мөгаен, сау-сәламәт кешеләр дә шиккә калып, поликлиникаларга барсыннар өчен эшләнә торгандыр.* Җ.Харисов. **Шиккә төшү** *к.* **шиккә калу**. *Кичкырын эштән соң өенә кайтып җитәрәк, Фәгыйлә үзләренең капка төбендәге эскәмиядә ике хәрби диңгезче утырганын күреп шиккә төшә һәм ихтыярсыз тукталып кала.* С.Сабиров. *Авыру кеше табибның йөзендәге, күзендәге һәр үзгәрешне дүрт күз белән күзәтеп тора, аз гына борчылу сизсә дә шиккә төшә.* М.Маликова. **Шик салу** Коткы салу; ышанмаучылык тудыру, шикләндерү. *«Татар булган җирдә хәтәр бар» дип Шик салганнар дуслар эченә.* Ш.Маннур. *1947 ел җәенең корылык афәте халыкның сугыштан соңгы өметле матур хыялларына шик салды.* М.Мәһдиев. *Ахуновның рус телен әйбәт белүенә шик саласым килми. Ул тәрҗемә эше белән дә шактый шөгыльләнде ---.* М.Юныс. **Шик тоту** Шикләнү, ышанычсызлык белдерү; гаепле дип уйлау. *Аз гына шик тоткан кешегез булса да, миңа җиткерегез.* Р.Вәлиев. *Мин үзем болай барлык шагыйрьләрнең иң яхшы шигыре мәхәббәт турында гына язылган булуына шик тотам.* Р.Фәизов. **Шик тотмау** Нык ышану, һич шикләнмәү, икеләнмәү. *Гали Рәхимә абыстайның һәм кызларның үзе белән танышуны кабул итүләрендә бер дә шик тотмый иде.* Ф.Әмирхан. *Хатыны моңа ышанмады, әмма әнисе шик тотмады: малаеның яхшылык эшләсә дә, начарлык эшләсә дә, чын күңелдән, шулай тиеш, шулай дөрес дип ышанып эшләвен ул белә иде.* М.Мәһдиев. **Шик төшү** Шикләнә башлау, шик туу. *Миңа тагын шик төште. Карале, гел бирнә, гел кияүгә чыгу турында сөйләнәләр бит. Тикмәгә генә түгелдер бу!* Г.Бәширов. *Рыкалов сатлыкҗан булмаган тәкъдирдә дә, мондый шик төшкәч, аны бригада командиры итеп калдырырга ярамый иде.* Г.Әпсәләмов. **Шик уяту** *к.* **шик салу**. *Ә менә Вахитның Ольганы өзелеп яратуы бер төрле дә шик уятмый.* Ә.Еники. *Гарем, деньга, чулки, багровый кебек сүзләрнең нигезендә хәрәм, тәңкә, чолгау, бавыр дигән сүзләр ятуы берәүдә дә шик уятмыйдыр.* Н.Әхмәдиев

**ШИКАЯТЬ** *и. гар.* 1) Берәр кеше яки оешманың ялгыш, законсыз, начар эшләрен яки гаебен күрсәтеп язган рәсми гариза; жалоба. *Россия империясенең Эчке эшләр министрлыгына газетаның Төркестандагы рус сәясәте өчен зарарлы булуы турында шикаять кәгазе килеп кергәннән соң, 1916 елның сентябрь аенда --- «Сүз» газетасы да ябыла ---.* Г.Исхакый. *Ә Арыслан утыра иде, план уйлап, Шикаятьне укыды да тирән сулап Язып куйды: «Фактлар юк кулымда, – дип, – Тикшерергә, ачыкларга урында!» – дип.* Г.Афзал

2) Оешма җитәкчеләренә, хөкүмәт вәкилләренә һ.б.ш. югары органнарга кемне дә булса берәр нәрсәдә гаепләп, яла ягып язылган яки телдән хәбәр ителгән яшертен әләк. *Яңгура теге вакытта --- Мансур Таһиров һәм аңа килеп кушылган Юматша Әхмәтшин, Татьяна Степановналар өстеннән язган зур шикаятен, Самуил Абрамович киңәш иткәнчә, үз кулы белән ертып ташламады, бәлки, Тютеевка китереп бирде.* Г.Әпсәләмов. *«Иптәш Сталин! Минем уемча, хәзер мин әйтәсе информацияне Сез белергә тиешсез». Жуковны яхшы белгән Сталин сагая: «Тагын берәрсе өстеннән шикаять бирә инде бу Маршал. Туймаса да кеше туймый икән».* З.Зәйнуллин

3) Зар, зар-моң; нәрсәдән булса да ризасызлык, канәгатьсезлек. *Ах син, адәм углы, бәхетеңнән шикаять итәмсең? Ул ярамый бит, ул Алладан шикаять була бит!* Ф.Әмирхан

**ШИКАЯТЬ-ДОНОС** *җый. и. гар.-рус* Һәртөрле әләк, донослар. *Газета өстеннән төрле шикаять-донослар, хәтта уйдырмалар бер-бер артлы явып торды.* А.Расих

**ШИКА́ЯТЬ ИТҮ** *ф.* 1) Берәр кеше яки оешманың ялгыш, законсыз, начар эшләрен яки гаебен күрсәтеп, рәсми гариза язу. *Овчинников: «Мин Татарстан прокуроры гамәлләрен Русиянең генераль прокуратурасына шикаять итәргә җыенам, бәйсез экспертиза үткәрүне таләп итәм», – дип белдерде «Свободная пресса» аша.* Н.Алан

2) Оешма җитәкчеләренә, югары органнарга берәр кешене нәрсәдә булса да гаепләп, яла ягып, яшертен хәбәр җиткерү, сүз сөйләү, әләкләү. *Ул кинәт йөзенә кызыллык йөгерүен сизде, майорга карамаска тырышты. «Әллә Сергей минем салкынлыгымны сизеп, майорга шикаять иттеме?» дигән уй миеннән йөгереп узды.* Х.Камалов. *«Атны куалап яндыргансың!» дип Шарук, авылның старостасына шикаять итеп, Төкәнәйдән ат бәясен түләттерде.* Р.Батулла

3) Нәрсәдәндер зарлану, кемгәдер зарыңны сөйләү. *Инде хатын иреннән бу илтифатсызлыкны күрдеме, аның йөрәге хәсрәтләр белән тула, миңа золым кыла, ди, еглай, бәхетсезлегеннән шикаять итә, үзенең кадерен белмәгән иргә туры килүеннән зарланадыр.* Г.Буби. *[Колтай:] Әйдә, әйдә. Муллаң өстеннән шикаять итеп йөрүнең ничек икәнен танытыйм әле (җилтерәтеп алып китә).* Т.Гыйззәт

**ШИКА́ЯТЬ КЫЛУ** *ф. к.* **шикаять итү**. *Сүзнең болай бетүен кунак үзенә фатиха дип аңлады, әдәп йөзеннән тагы берничә моң-зарын әйтте, дөньядан шикаять кылды: – Өметем зур иде, бу талашларның чиге күренми, күңелем бозылып калды, Бирем әкә, – дип, кулына камчысын алды.* Г.Ибраһимов. *Юк-бар кешеләргә кергәләп, идарәгә төшмәвеннән үк күңеле бизгән иде аның Нәҗиптән. «Аның авызы тулы гайбәт! Бер дә юньле сүзе юк!» – дип, Зәйнәп килеп шикаять кылгач, ышанып та бетмәгән иде Ихлас...* А.Гыйләҗев

**ШИКАЯТЬЛЕ** *с.* 1) Шикаяте булган, шикаять иткән. – *Минем дә хатыным шундый ук хезмәтләрне үземә күрсәтә. Мин дә сабырлык белән түзәрмен, – диде шикаятьле ир.* Ф.Яхин

2) Зарлану һ.б.ш.ны белдергән, зар-моңлы. *Сөембикәнең тәүге ире*

*Җангали хан белән ничектер хисләре берегеп җитмәде. Кадер-хөрмәткә күнеккән иркә туташ моны бик авыр кичерде, атасына шикаятьле хатлар язды, аннан яклау көтте.* М.Әмирханов

**ШИКАЯТЬНАМӘ** *и. гар.-фар.* Язма шикаять. *Ильминскийның биографы П.Знаменский сүзләренә караганда, югарыда телгә алынган шикаятьнамәне Ильминский үзе генә язган һәм, хисабын саллырак, абруйлырак итү өчен, күрәсең, Саблуковның да аңа кул куюына ирешә алган.* А.Тимергалин. *Галимҗан --- теге галим булырга җан атып йөргән язучы шикаятьнамәсен көнләшү чире дип атады.* С.Поварисов. *Институт хезмәткәрләре тарафыннан югары органнарга хезмәт хакларының бик түбән булуы турында язылган шикаятьнамә җавапсыз калды*

**ШИКАЯТЬЧЕ** *и.* 1) Шикаять (*1 мәгъ.*) бирүче, шикаять (*1 мәгъ.*) белдерүче кеше; *русчасы*: **жалобщик**. *Сиксәненче еллар башында шикаятьчеләр, әләкчеләр өчен бер рәхәт вакыт булып алган иде. Өстәге төрле оешмаларга имзалы, имзасыз яуган хатларның санын-исәбен шайтан үзе дә белмәгәндер.* Р.Зәйдулла

2) *юр.* Нинди дә булса бәхәсне хәл итү максаты белән судка һ.б.ш. органнарга дәгъва белдерүче, дәгъва итүче, дәгъвачы; *русчасы*: **истец**. *Профессиональ шикаятьчеләр тырнак астыннан булса да кер табып, шуны күпертәләр, һәм менә китә тикшерүләр, эшләп торган булдыклы кешеләрне юкка чыгарулар...* Ә.Исхаков

**ШИКӘР** *и. һинд.* 1) Чөгендер яки камышның махсус төреннән җитештерелгән, татлы ак кристаллик матдәләрдән торган азык продукты. *Тәзкирә --- әйберләр куелган киштәләр арасына күз салды – прилавка өстендә генә эреэре шакмак шикәрләр ята.* Ф.Яруллин. *Чәйнекне --- самавыр өстенә утырткач, шүрлектән ак чүпрәк төенчекне үрелеп алды. – Бәбекәем, шикәрне ватып бирсәң...* А.Әхмәтгалиева

2) Сөткә шикәр (*1 мәгъ.*) кушып кайнатылган, кызарып кайнавы җиткәч, атланмай кушып катырылган татлы ризык. *Динара белән Эльнара да сынатмадылар, Лилия ярдәмчеләре булышлыгында катлама белән кайнаткан шикәрне бик матур итеп тәкъдим итте ---.* Татарстан яшьләре. *Табында юка һәм кабартма, өйдә салган икмәк, кайнаткан шикәр.* Безнең гәҗит

3) *махс. күпл.* **шикәрләр**. Углеводлар төркеменә кергән кайбер органик кушылмаларның гомуми атамасы. *Шикәрләр химик юл белән синтезлана*

4) *тарт. форм.* **шикәрем**. Үз итеп, яратып, иркәләп, якын итеп атау, эндәшү, мөрәҗәгать итү сүзе. *[Әминә:] Иркәм, сөеклем! Шикәрем син, балым син, Солтангәрәй!* А.Гыйләҗев. *Хатын: – Өйләнгәнче син һәрвакыт, Гүзәлем, җаным, дидең. Тәмле сүзләр күп сөйләдең. Шикәрем, балым, дидең.* Ш.Галиев

5) *күч.* Иң кадерле, бик кирәкле, әһәмиятле, кыйммәтле, мөһим нәрсә. *Соң бит тоз ул – халыкның шикәре.* Ф.Кәрим

**ШИКӘ́Р АВЫРУЫ** *и.* Кан составында шикәр күбәю һәм сидеккә шикәр бүленеп чыгу белән бәйле диабет авыруының бер төре. *Ул шикәр авыруы белән җәфаланды.* Ф.Яхин. *Больницадагы табышларым шул булды: стресстан шикәр авыруы башлану белән «котладылар» ---.* Ә.Зарипов

**ШИКӘ́Р ДИАБЕТЫ** *и. к.* **шикәр авыруы**. *Ә менә бу юллама – канга гомуми анализ, шикәр диабетын белү өчен...* Г.Ахунов. *Җитмәсә, соңгы елларда аны шикәр диабеты дигән каһәр төшкән авыру борчый башлый.* Т.Нәҗмиев

**ШИКӘ́Р КАМЫШЫ** *и. бот.* Кыяклылар семьялыгыннан киң эре яфраклы, себеркәч чәчәкле, сабагыннан сыгып алынган согы шикәр әзерләү өчен кулланыла торган күпьеллык тропик яки субтропик үсемлек. *Машиналар комбайннан төшкән шикәр камышын заводка ташыйлар.* Р.Ибраһимов. *Илнең субэкваториаль һәм тропик өлешләрендәге яр буе тигезлекләрендә ананас, банан, шикәр камышы һ.б. үстерәләр.* Материклар һәм океаннар географиясе

**ШИКӘРЛӘНҮ** *ф.* 1) Шикәргә әверелү, шикәргә әйләнү. *--- март ае булса да, аларның баллары шикәрләнмәгән, ягъни утырмаган, кичә генә суыртып куйган төсле сап-сары, сәмих сагыз диярсең!* А.Гыйләҗев. *Крахмал сульфат кислотасы тәэсирендә шикәрләнә.* Кызыклар дөньясында

2) Шикәр комы кебек кристаллар барлыкка килү, кристаллашу. *Алга таба да кызыл балчык катламы ком белән аралашып барды: я ул сыек плывунга әверелә, я шикәрләнеп ката.* К.Кәримов. *Кар шикәрләнде, учка алсаң, аннан су тамып тора.* Ф.Садриев

3) Татлылану; тәмлеләнү, шикәр тәме керү. *Күзләр як-якка карана, күңелдә бер генә уй – пешкән бәрәңге. Күптән инде суынып өлгергән, шикәрләнгән шул бәрәңге тәмен мин әле дә тел очында тоям кебек.* Ф.Садриев

**Шикәрләнә башлау** Шикәрләнергә тотыну. *Әйтик, кайбер варенье саклаганда я әчи, я шикәрләнә башлый.* Сөембикә

**Шикәрләнә төшү** Берникадәр шикәрләнү; тагын да шикәрләнү. *Былтыргы вареньем барые барын. Тик бераз шикәрләнә төшкән.* Ф.Яруллин

**Шикәрләнеп бетү** Тәмам шикәрләнү. *Үзләре хәтле «татлы вата» күтәреп, битләре шикәрләнеп беткән балаларны карап торуы бер тамаша.* Әлки хәбәрләре

**Шикәрләнеп китү** Кинәт шикәрләнү. *Бал куерып шикәрләнеп китсә, аны аз гына җылытып алырга кирәк.* Әлмәт таңнары

**Шикәрләнеп тору** Әле, хәзерге вакытта шикәрләнү; даими яки әледәнәле шикәрләнү. *Камыры нәзек, йомшак, шикәрләнеп тора.* Мәдәни җомга

**ШИКӘРЛӘТӘ** *рәв.* Шикәр белән, шикәр хәлендә. *Чөгендердә эшләү, бер яктан, әнисенең эш урынын саклап калса, икенче яктан, көзен бераз акчасы да була, я чөгендерләтә, я шикәрләтә бирәләр шунда.* Ф.Бәйрәмова. *Малайларга мин җә шикәрләтә, җә йөземләтә ришвәт бирә башладым.* Р.Батулла

**ШИКӘРЛӘ́Ү** *ф.* Шикәр өстәү, шикәр салу; шикәрле, татлы итү. *Куе, кайнар чәйне шикәрләп, ипиләп эчкәннән соң, әйбәт кенә киенеп, әле яктырып та җитмәгән, тапталмаган, пычранмаган кышкы буш, тын урамга чыгасың.* Ә.Еники. *Әтисе, әнисе аны Бик иркәләде. Ашатканда бик майлады. Бик шикәрләде.* С.Баттал

**Шикәрләп кую** Алдан ук яки тиз генә шикәрләү. *Шуннан соң пыяла банкага тутырып, шикәрләп куясың.* Ватаным Татарстан. *«Казан ашханәсе» хезмәткәрләре кышка 30 килограмм каен җиләге һәм караҗиләк шикәрләп куйган.* Татарстан яшьләре

**ШИКӘРЛЕ** *с.* 1) Составында шикәр булган, шикәр салып әзерләнгән, шикәр белән татлыландырылган. *Йокысы килсә дә елады, йокысы туйса да елады; шикәрле сөт белән туйдырылса да елады.* Г.Исхакый. *--- әрәмтамаклыгым да бик чамалыдыр хәзер: авызыма каба алганым шикәрле чәй дә бәрәңге боткасы ---.* Ф.Баттал. *Сыерга шикәрле су эчерт инде хәзер.* Р.Бәшәр

2) Татлы, баллы, төче. *Тизрәк самавыр куярга кушты, малайны шикәрле булкилар, шоколадлар, алма, виноградлар алырга йөгертте* ---. Г.Ибраһимов. *Аның күзләре авырта һәм ул ике күзенә ике төрле дарудан тамчылар тамыза иде. Берсе – ачы, икенчесе – шикәрле.* М.Мәһдиев

3) Табигый шикәре булган, татлы. *Алма шикәрле булсын өчен, кояш та кирәк...* Ш.Галиев

**ШИКЕЛЛЕ** *бәйл.* **1.** 1) Бер нәрсәне икенче нәрсә белән чагыштырып, тиңләштереп, охшатып әйткәндә кулланыла: кебек, төсле, ише, охшаш. *Искәндәрнең --- чия шикелле кызыл, шактый калын иреннәреннән яшьлек, тазалык җиле исеп торадыр иде.* К.Тинчурин. *Көн юк, төн юк, ял бирмиләр, бәйрәм димиләр, ат шикелле эшлисең дә эшлисең, юньле сүз дә ишетмисең.* Т.Гыйззәт. *Көзгедәй ялтырап торган төрәннәр кара карга канаты шикелле чем кара, симез туфракны уйнап кына актаралар.* Г.Әпсәләмов

2) Бер-беренә нинди дә булса үзенчәлекләре белән охшаш нәрсәләрне санап киткәннән соң, шундый ук әйберләр тагы да барлыкны күрсәтә. *Сезнең якка, бәлки, намазлык, комган, сөлге, эскәтер, чалма, чалма бүрек шикелле нәрсәләр дә китә торгандыр?* Г.Камал. *Мөҗип эшләпә тотып иптәшләреннән көзге, йөзек, кульяулык шикелле әйберләр җыя.* М.Хуҗин. *Халык файдасына балта, көрәк, сәнәк, чабагач, капчык шикелле нәрсәләрне бер амбарына куеп, хаҗәте төшкән кешеләр шуннан алып, бушагач, урынына китереп куяр булганнар.* Р.Зарипов

**2.** *и. мәгъ.* Үзеннән алдагы сүз белдергән предмет кебек кем яки нәрсә; башка шундыйлар. *Рядовой колхозчы булып калу башта аңа түбәнлек булып тоелса да, тора-бара күнегер, ул да бүтәннәрдән ким эшләмәс иде. Аның шикелләләр эшләделәр бит.* В.Нуруллин. *Фәтхерахман Әхмәдиев, Ганс Сәйфуллин, Фәрит Хатипов, Илгиз Закиров, Рамил Курамшин шикелләләр җырлар яза, композитор булып китә.* Р.Миңнуллин. *Синең шикелләләр гади адәм балаларының хәле белән артык кызыксынып тормый.* М.Кәбиров

**3.** *терк. мәгъ.* Баш һәм иярчен җөмлә арасында чагыштыру – рәвеш мөнәсәбәтен урнаштыра. *Бу юлларны укыганнан соң, Ганс, яшен суккан шикелле, акылын югалтты.* Г.Кутуй. *Ярканат яктыда күрмәгән шикелле, мин дә нәрсәләрнедер абайлап бетермим кебек.* Х.Камалов. *Кайтып чәй эчәргә утырган идем, кемдер тәрәзәгә чирткән шикелле тоелды, үрелеп карадым.* М.Маликова

**4.** *кис. мәгъ.* Берәр нәрсә турында икеләнүне, чамалауны белдерә: бугай, кебек. *Холодецның Зәйне Алкиннан аерып куюының нииндидер сере бар шикелле.* Х.Камалов. *Күке кычкыра да кычкыра икән. Әти һич кенә дә таба алмый. Кайдадыр якында гына да шикелле, ә үзе һаман күренми.* З.Хәким. *Миңа калса, рәссамга күп гыйлем кирәкми дә шикелле, чөнки ул фикерне чуалтырга, таркаулыкка китерергә һәм иҗат өчен зыянлы булырга мөмкин.* М.Мәһдиев

**ШИКЛӘНДЕРҮ** *ф.* 1) Шикләнергә, шөбһәләнергә мәҗбүр итү, шөбһәләндерү. *Чынбарлык исә кешене һәрчак шикләндерә, икеләнергә мәҗбүр итә.* М.Хәбибуллин. *Карчыкларның тәртип-гамәлләре Хәлимне шундук шикләндерде.* Г.Гыйльманов. *Чиркәү чәүкәсе кебек таң тишегеннән торып утыруы да шикләндергән иде ул Ванька шалапайның.* Ф.Баттал

2) Куркыту, шомландыру. *Шундый чакта үземне карурман авызында басып торган ялгыз юлчыдай сизәм. Кирәргә, үтәргә кирәк миңа аны, әмма таныш түгел урман юлы шикләндерә, шомландыра да үземне.* Л.Ихсанова. *Эчкә керүдән нидер тыя, нәрсәдер шикләндерә иде.* М.Маликова

**Шикләндерә башлау** Шикләндерергә тотыну. *Нишләргә дә аптыраш. Әллә шәһәргә чыгып, бераз йөреп керергәме? Алай итсәң, Әхәт белән аймылыш булырбыз дип куркам. Монда, ишек катында утыру да шикләндерә башлады.* А.Хәсәнов. *Маһирәнең дә балага чат ябышуы, әнисенең аны һаман хуплап торуы да нык шикләндерә башлады.* Г.Галиева

**Шикләндерә төшү** Бераз шикләндерү; тагын да шикләндерү. *Бу эчпошыргыч тынлыкны тизрәк бозасы килеп: – Ни бар, әни? Берәр нәрсә юктыр бит? – дип сорады. Әнисе, аны тагын да шикләндерә төшеп, җавап бирергә ашыкмады.* Ә.Сафиуллин. *Бу нәрсә Мөршидәне шикләндерә төште.* Ватаным Татарстан

**Шикләндереп җибәрү** Кинәттән шикләндерү. *– Җиңеләеп китәрсең, – диде ул, аның хәленә кирәргә теләгәндәй. – Шикләндереп җибәрдең син мине...* Ә.Сафиуллин. *Җитмәсә Госман: – Ярар, арт сабакларын укытыр көн дә булыр әле бер! – дип, аларны тагын да шигәйтеп-шикләндереп җибәрде.* И.Салахов

**Шикләндереп кую** Көтмәгәндә шикләндерү. *Менә хәзер аның сабыйны имезеп йөрүе әллә Людмиланы, әллә Исмәгыйльне шикләндереп куйды...* Ә.Сафиуллин. *Авыру янында шуннан да озаграк тоткарланса, шикләндереп куюың да бар бит!* Г.Әдһәмова

**Шикләндереп тору** Һәрвакыт, гел шикләндерү; әледән-әле шикләндерү. *Аның миңа беркайчан да ошамаган, һәрвакыт шикләндереп торган бер сыйфаты – ул беркайчан да җиңелми иде.* М.Кәбиров. *Мишәр мәсьәләсе борчып, шикләндереп торган иде.* Д.Исхаков. *Исеңдәме, синнән гаеп Эзли иде күзләрем, Шикләндереп тора иде Һәр хәрәкәт, сүзләрең...* Ә.Низамова

**ШИКЛӘНЕЛҮ** *ф.* 1) *з.-сыз к.* **шикләнү**. *Андый чакта шикләнелә шул – тиз генә карар кабул итүе читен*

2) *төш. юн. к.* **шикләнү**. *Беренче тапкыр сорау алырга чакырылган шаһит, шикләнелгән адәм белән сөйләшү еш кына уңай нәтиҗәләргә китермәскә мөмкин.* Т.Әйди. *Тикшерүче, тамерланлылар төркемендә йөриләр, дип шикләнелгән берничә егетне чакыртып сөйләште.* Ф.Имамов

**ШИКЛӘНЕЛҮЧЕ** *и. юр.* Җинаять эшләүдә гаепле дип шикләнелгән, шикле дип күрсәтелгән кеше; *русчасы:* **подозреваемый**. *Казанда янган йортта табылган ир-атны үтерүдә шикләнелүче тоткарланган.* Акчарлак. *Хәзерге вакытта җинаять кылуда шикләнелүче сак астында һәм эш РФ Тикшерү Комитеты карамагына җибәрелде.* Йолдыз

**ШИКЛӘНЕ́РДӘЙ** *с. к.* **шикләнерлек**. *Рәүф кулын күтәргәч, тын калдылар. – Шикләнердәй нәрсә күрмәдегезме? – дип сорады ул Өлфәтләрдән.* А.Тимергалин. *Ул --- башта каралтыкураны урап чыкты. Шикләнердәй нәрсә тапмагач, тышкы ишекне тартып карады: бикле.* Н.Әхмәдиев

**ШИКЛӘНЕРЛЕК** *с.* Шик сала торган, шик тудыра торган. *Поцелуйкинны күзәтүче Куркынычсызлык сакчылыгы бүлеге кешеләре аның турында шикләнерлек яңа нәрсә хәбәр итмәделәр.* Г.Әпсәләмов. *Шикләнерлек нәрсә юклыкка тәмам ышангач кына, Гөлбануны, кулыннан тотып, ишегалдына алып керде.* М.Хәсәнов. *Ләкин ул*

*боерыкта мин шикләнерлек нәрсә тапмадым.* В.Нуруллин

**ШИКЛӘНМИЧӘ** *рәв.* Икеләнмичә, шөбһәләнмичә, хаклыгына ышанып. *Наилдән: «Ничек, ни хәлләрдә яшәп ятасыз?» – дип сорасалар, әле аның шикләнмичә һәм һич икеләнмичә: «Әйбәт! Без бик бәхетле!» – дип, чатнатып җавап бирә торган чагы иде.* А.Гыйләҗев. *Әгәр кем дә булса берәү: «Балачакның иң матур билгесе нәрсә?» – дип сораса, бер дә шикләнмичә әйтегез: кибеткә ипи алырга килгән баланың, кибет ишегеннән чыгып барышлый түзә алмыйча, ипинең почмагын тешләп алуы.* М.Мәһдиев

**ШИКЛӘНҮ** *ф.* 1) Нәрсәгә дә булса ышанып җитмәү, тулы ышаныч булмау; шөбһәләнү. *Икесе дә бераз дулкынланганнар иде, --- юл буенча сөйләшмичә бардылар, аннары шофёр татар булып чыкмасын дип тә шикләнделәр, ахрысы.* Ә.Еники. *Аның нидер күз алдына китереп, нидер уйлап, шикләнеп карап куюлары Зөлфия йөрәгенә уктай кадалды, утлы тимер сымак өтте.* Н.Хәсәнов

2) Нәрсәнең дә булса үтәлүенә, тормышка ашачагына, реальлегенә ышанып бетмәү, икеләнү. *[Хәлил Фәтхиевич]: – Фетны яраткан кешедән бик һәйбәт рус әдәбияты укытучысы чыгачагына мин шикләнмим, – диде.* М.Мәһдиев. *Ләкин соңгы вакытларда үзенең моңарчы гел яклап килгән дәвалау методына шикләнеп карый башлады ул.* Ф.Яруллин

3) Куркыныч көтү, хәвеф-хәтәр булыр дип уйлау, хәвефләнү, шомлану. *Сайфиянең биек коймасы Иделнең сөзәк яр өстеннән үк башлана, бу якта кечкенә капка гына бар. Аны төнгә дә бикләмичә калдыралар, бүре-фәлән керүдән дә, чит-ят сугылудан да шикләнмиләр ---.* М.Хуҗин. *Ни күрик, шунда гына немецларның кыр кухнясы. Ике агрегат. Мичләре ягулы. Шикләнмиләр дә, бәдбәхетләр.* М.Әмирханов

4) Курку, куркып калу, шүрләү, шиккә калу. *Милиция майоры --- сиздермәскә тырышып кына, утыргыч кесәләрен капшап алды. Сәет күзеннән бу хәрәкәт читтә кала алмады: сөйләшүне язып баручы нәмәстәкәйләр эзли. – Зинһар, шикләнмәгез, курыкмагыз. Без – җитди кешеләр.* Т.Галиуллин. *Ул тамак кырып куйды, кыенсынып кына: – Шикләнмәгез, бу йортта сезне начарлык көтми, монда тәртипле кешеләр яши, – дип өстәде.* Р.Габделхакова. *Ул, хатынының караңгыдан шикләнеп сөйләнүен белсә дә, юатырлык сүз катмады, аны узып, алга атлады.* Сөембикә

**Шикләнә башлау** Шикләнергә тотыну. *Ул, җитәкченең авызына карап, аның авызыннан чыккан сүзне эләп алып язып куярга шундый түбәнчелек, шундый кечелек, шундый бәйлелек белән хәзер тора, аның бу кыяфәтенә карап кызгана һәм шикләнә башлыйсың ---.* Г.Бәширов. *Зөһрәне дә артык мактарга ярамый, хатын шикләнә башлар.* Ф.Яруллин

**Шикләнә төшү** Бераз шикләнү; тагын да ныграк шикләнү. *Эшләр болайга киткәч, Самат абый шикләнә төште: – Ярый, ярый, бетте, – диде.* В.Нуруллин. *Бу карашта Рәфиснең яңа халәтен аңларга тырышу да, бераз шикләнә төшеп, нидер көтү дә...* А.Вергазов

**Шикләнеп йөрү** Озак вакытлардан бирле шикләнү. *Мин үзем бер җирдә түгел микән дип шикләнеп йөрим әле.* Т.Гыйззәт. *--- ә ул, тиле, күпме кара сөремен коеп, алардан шикләнеп йөрде.* Ә.Еники

**Шикләнеп калу** Ниндидер сәбәптән соң шикләнә башлау. *Ирис, сөененеченнән бусага аркылы сикерәм дигәндә, никтер шикләнеп калды.* К.Кәримов. *Шикләнеп калган малайлар Марсельне селкеткәләргә керештеләр.* Р.Галиуллин

**Шикләнеп китү** Кинәт, көтмәгәндә шикләнә башлау. *--- өйдә утыра идем дә, Әхмәтзәки белән хәзрәтнең кереп киткәнен күргәч, күңелем шикләнеп китте.* Т.Гыйззәт

**Шикләнеп кую** Аз гына вакытка, беразга гына шикләнү. *Вакыт-вакыт хыялым эше түгелме икән бу дип шикләнеп тә куям, әмма барыбер Фатих Әмирханны башкача күз алдыма китерә алмыйм.* Ә.Еники. *Хәтта аның техниканы белүенә шикләнеп тә куясың.* С.Шәрипов

**Шикләнеп тору** Күпмедер вакыт шикләнү; әле, хәзерге вакытта, сөйләү моментында шикләнү. *Мин, курка-курка гына, аның болдыры янына килдем дә керергәме, юкмы дип шикләнеп торам икән.* Ә.Хәсәнов. *Аяз да, бераз шикләнеп торгач, касәне авызына каплады.* Р.Сәгъди

**ШИКЛӘНҮЛЕ** *с.* Шикләнүне белдергән, шикләнү чагылдырган. *Алар шунда ук барысы да сикерешеп тордылар һәм, бер-берсенә шикләнүле һәм ачулы карашлар ташлап, төрлесе төрле якка әкрен генә артка таба чигенә башладылар.* Р.Мөхәммәдиев. *Егет шулай кыз күңелендәге шикләнүле уйларын юкка чыгарырга теләде.* С.Зыялы

**ШИКЛӘНҮЧӘН** *с.* Һәрнәрсәгә шикләнеп карый торган, ышанмаучан. *Мондый киеренке вакытта артык шикләнүчән буласың икән.* С.Сабиров. *Официантлар, ашыга-ашыга, өстәлләрне җыештыра, кайбере безгә шикләнүчән сак караш ташлап ала.* М.Вәлиев

**ШИКЛЕ** *с.* **1.** 1) Ышанычсыз, чит, ят. *Сүзгә Надыйров кушылды. Әлеге шикле Кара Гайнетдин дигән кешенең кайсыдыр яктан Газиларга чак кына чыбык очы булуы турында сүз куертып алды.* М.Хәсәнов. *Мине машина йөртергә өйрәтүче кеше бик шикле күренде. Минем тол хатын икәнлекне белептер инде, әллә ничегрәк итеп карый бу миңа.* Т.Миңнуллин

2) Шөбһәле, ышанычлы булмаган, асылы билгесез, шик тудыра торган. *Бардыр, берәр шикле нәрсә бардыр дип, шомланып, иң элек тәрәзә пәрдәсенең бер читен күтәрде.* З.Хөснияр. *Мондый дәү ирләрне элек Киев, Одесса, Варшава кебек шәһәр читендәге шикле кунакханәләрдә төнге швейцар сыйфатында күрергә була иде.* М.Галиев. *Кемнәрдер, аракы, самогонга алмаштырып, капчык-капчык балык, тозлы икра төяп китәләр икән. Милиционер шуны эзләп килгән, берәр шикле судно күрмәдегезме, дип сораштырды.* С.Сабиров // Начар, хәләл булмаган, яман нәтиҗәләргә китерү ихтималы. *Фабарисовның аны ниндидер пычрак, шикле эшкә этеп кертергә маташканын ул инде аңлый башлаган иде.* Ф.Бәйрәмова. *Р.Кутуйның бай рухлы геройлары дөнья малы белән сыналуга бирешмиләр, шикле юллар белән максатка ирешү, кемдер башка берәү исәбенә җиңел тормыш алып бару, ничек тә булса җайлы яшәү коткысына бирелмиләр.* Г.Ивлев

3) Шикләнүле, ышанмаучан. *Тикшерүчегә Җәүдәт турындагы шикле уйларны чишкәнче, егетнең үзен күрергә иде.* Ф.Яруллин. *Ул үзенә булган салкын, шикле карашны аңлый иде, ләкин бу турыда беркемгә дә әйтми иде.* Р.Батулла. *Рәмилә шикле тавыш белән җавап кайтарды: – Биредә булса, ни булган?* Х.Ширмән

4) Куркыныч, хәтәр, шомлы. *Андыймондый шикле хәл-хәбәрләр ишетелгәне юк. Дөрес, бер кызны, совет гаскәриләре күмелгән каберлектә кул букчасын,*

*андагы кәгазьләрен онытып калдырганы өчен, кабаттан СССРга кайтарып җибәрделәр.* К.Тимбикова. *Авыл урамында тезелеп үскән биек-биек тирәк һәм каеннарның куе ябалдашларында ник бер яфрак тибрәлсен дә ник бер шикле өн колакка чалынсын.* М.Маликова

5) Шик астына алынган, хөкүмәткә ышанычсыз дип табылган. *Шәһәрдә төрле шомлы хәбәрләр йөри, тентүләр, кулга алулар да көчәйгән, шикле кешеләрне чүпләп кенә торалар икән.* Ф.Әмирхан. *Сөйләшүләренә караганда, бу халык арасында караклар, документсыз шикле кешеләр дә бар, аларны аулау максаты белән әледән-әле тикшерүләр үткәреләр, документсыз шикле кешеләрне кулга алалар икән.* С.Сабиров. *Ул – үзе шикле элемент, үзе буржуй калдыгы, шуңа күрә кулакларны яклый, дигәннәр.* Р.Батулла

**2.** *и. мәгъ.* Шик тудыра торган, ышанычсыз дип табылган кеше. *Алар килеп җиткәч тә, Сабан туе беткәч тә, Шикленәрне тентибез, Кайгырмагыз сез һич тә.* Т.Гыйззәт. *Баштарак шундый бурыч куелды: легионерларның уй-фикерләрен өйрәнергә, шикленәрне күзәтү астына алырга, хәлиткеч минутта кемгә таянырга икәнлеген ачыкларга.* Р.Мостафин

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Шик белән, шикләнеп, ышанмыйча. *Аның почмак якка шикле карана-карана боргалануын күргәч, үземдә җирәнү хисе туды, --- ләм-мим сүз катмыйча чыгып киттем.* С.Сабиров

2) Шик уятырлык рәвештә, сәер итеп. *Фира, шикле кабаланып, Алексейга караган көе, сумкасын актарды һәм бер рәсем чыгарды.* Х.Камалов

**4.** *хәб. сүз мәгъ.* Икеле, ышанычсыз. *Аннан соң кунакханәләрдә бронең булмаса, бик ашкынып көтеп тә тормыйлар, бигрәк тә җәй уртасында буш урыннар булуы шикле.* Р.Батулла. *Хан кызы Идегәйгә гашыйк, әмма бу мәхәббәтнең уңышлы була алуы шикле.* Т.Галиуллин

**ШИКЛЕЛЕК** *и.* 1) Шикле булу хәле, ышанычсызлык. *Үзен тотуының шиклелеге*

2) Шикчеллек, ышанмаучылык. *Ул үзе куйган сорауларның берсенә дә ышанып бетми, булмастай дип саный, артык шиклелеге, вакчыл тәфтишлеге өчен үзен үзе сүгә ---.* Р.Сибат. *Битараф булган очракта бу холык үз-үзенә карата кызгану, әрнүгә яки кырыслылыкка әйләнеп кайтачак, ә баланың куркулары явызлык, шиклелек һәм кансызлыкка әйләнергә мөмкин.* Сабантуй

**ШИКМӘ** *и.* Өй яки каралтының түбә түшәмәсе астында бәпкәләргә аркылы китереп салына торган киртә яки такталар. *Гөрләп торган авыл клубының Тырпайган тик шикмә башлары. Урамында, хәтер йомгагыдай, Тәгәрәшкән нигез ташлары...* Р.Зәкуан. *Яфраклы агачлар бәпкә, шикмә, бина эчендәге бүлмә такталары, эчке ишекләр, плинтуслар, ырмаулы борыслар, ишек-тәрәзә йөзлекләре, идән-түшәм такталары ясау өчен яхшы.* Төзү материаллары

**ШИКСЕЗ** *рәв.* **1.** Һич икеләнмичә, һич шикләнмичә, тәгаен. *Ул: «Дөресме бу?» – дип кайтарып сорарга теләмәде, ул мондый зур эштә Ушаковның гадел, туры булуына бер шиксез ышанырга теләде.* Ә.Еники. *--- кыр казлары оча, безнең якларга килә иде – бу инде бик яхшы, бик мөлаем күренеш, бу инде бер дә шиксез яз килде дигән сүз иде ---.* М.Мәһдиев

**2.** *с. мәгъ.* Анык, ачык, яхшы күренә, сизелә торган. *Аның бөтен кыяфәтендә үзен көтә-көтә көтек булганнарына һәм ул килгәч сөенәчәкләренә шиксез ышаныч ярылып ята иде.* М.Маликова. *Кара ничек ялагайланып елмая! Ташлама ясалуга шиксез ышаныч белән утыра!* Ф.Садриев

**3.** *хәб. сүз мәгъ.* Анык, төгәл билгеле. *Без, ике һәвәскәр «детектив», ышанычлы нәтиҗәгә килә алмадык алуын, ләкин каракның гади бер мужик түгеллеге, ифрат сак, үзенчә пөхтә һәм зыялы булуы шиксез иде.* А.Тимергалин. *Садирәләргә еш килеп йөрде егет, монда аңа ишек һәрвакыт ачык иде, аның гелгә үз кеше булачагы шиксез иде.* М.Хуҗин

**4.** *кер. сүз функ.* Әлбәттә, һичшиксез, бернинди шөбһәсез. *Һәрбер язучының теге я бу идеяне формалаштыруда аның субъектив аерымлыклары, шиксез, зур роль уйный.* Һ.Такташ. *Төшләр барысына да диярлек бертөрле керә, хәбәрсез югалган яки үлгән солдат ак күлмәк-ыштаннан күренә, бик күбесе тальян уйный, бу инде, бер дә шиксез, исән булуга ишарә, тальян уйнау, бер дә шиксез, юл төше инде ул ---.* М.Мәһдиев

**ШИКСЕНҮ** *ф.* Бераз гына шикләнү, шик тоту. *Шул рәвеш торганда куркып, шиксенеп, Көн аязды елдырымны читсенеп. Күктә чылбыр әйләнүдән туктала, Ут вә очкыннар бетә, күк тын кала.* Ш.Бабич

**ШИКЧӘН** *с. к.* **шикләнүчән**. *«Алай икән» дип шикчән кешеләр генә әйтә.* Т.Миңнуллин. *Карт --- Мусага карап алды. Аның эчтәнрәк карый торган шикчән күзләрендә һәм нык йомылган калын иреннәрендә «Күреп карыйк, кемдер бит әле» дигән төслерәк мәгънә ята иде.* Ш.Маннур

**ШИКЧЕЛ** *с. к.* **шикләнүчән**. *Шикчел, сагаюлы, сәләте чамалы бәндә, гадәттә, һәр үткен сүздән дерт итеп китә, кара коелып чыга.* М.Галиев. *Ул, шикчел уйларны яңадан куып, үзен тынычландырырга, бүтән алар белән башын интектермәскә карар бирде.* А.Вергазов

**ШИ́К-ШӨБҺӘ** *җый. и.* Һәртөрле шикләр, шөбһәләр, икеләнүләр, тәрәддүт. *Ире чирләгәннән бирле Наиләнең чыраеннан сөенү качкан иде, аның чибәрлеген өзмәс нужа, туя ашамау, курку, икеләнүләр, шик-шөбһәләр йоткан иде.* А.Гыйләҗев. *Менә шул шик-шөбһәләр, башына килгән төрле уйлар да аны бимазалады.* Р.Кәрами

**ШИЛ** *и. диал.* Эчкә бату, иңүдән барлыкка килгән чокыр, урын. *Үсә куйды Идегәй. Бер яшендә бер икән, Баскан җире шил икән. Ике яшьтә ил булды, Әйткән сүзе им булды.* Дастан

**ШИЛА́У** *ф.* Ши-и иткән тавыш чыгару. *Ат кузгалды. Чана кар өстеннән шилап, сызгырып китә башлады.* Г.Ибраһимов

**ШИ́Л БУЛУ** *ф.* 1) Эчкә бату, убылу, иңү, чокыр хасил булу. *Берне орган, икене орган, орган җире шил булган.* Н.Исәнбәт

2) *к.* **шилү** (*3 мәгъ.*). *Бүген ул да чал булды. Йомыркасын салганда, Картлыгыннан шил булды.* Дастан

3) *куч.* Тынлык урнашу, тынып калу, хәрәкәт туктау. *Көндезләрен начальниклары, старшийлары бик күп йөргәнгә, мин аяк асты шил булгач кына, проверкалар беткәч кенә яза идем.* Г.Исхакый. *Төн ярымында урталык шил булып, һичкая да бер шылт иткән тавыш калмый.* Ш.Камал

**ШИЛЕК** *и. төрки бот.* Кузаклылар семьялыгыннан каурыйсыман катлаулы яфраклы, сары чәчәкле, чәнечкеле куак яки вак агач; челек, чилык; *русчасы*: **чилига**. *Анда, тау итәгендә, --- шилек, тубылгы чыбыклы тигезсез урыннар.* Г.Ибраһимов. *--- бакча янында гына таулар бар, шилек үсә.* Туган як. *Шилек себеркесе*

**ШИ́ЛЛИНГ** *и. ингл.* 1) Төрле чорларда төрле Европа илләрендә әйләнештә булган акча берәмлеге // 1971 елга кадәр Англиядә фунт стерлингның

егермедән бер өлешенә тигез акча бирәмлеге. *Парижда һич сатулашу юк. Мин күлмәкләр алган мәгазәдә уйнап сатулашкан идем, --- бер шиллинг төшерделәр.* С.Максуди. *Җәлладны кулга алалар. Тегесе исә шакката: «Ни өчен? – ди ул. – Мин үз эшемне генә башкардым. Бер баш өчен миңа алтышар шиллинг түләделәр!»* С.Юзеев

2) Хәзерге вакытта Австрия һәм кайбер Африка илләрендә (Кения, Танзания һ.б.) төп акча берәмлегенең атамасы

3) Әлеге кыйммәткә ия булган акча

**ШИЛҮ** *ф. диал.* 1) Өрелгән, һава тутырылган куыш нәрсәнең һавасы чыгу, бушау. *Чәкчәк пешергәндә, май сүрәнәебрәк китсә, алар кинәт кенә суырылалар да эчләрен җыялар. --- Шилү диләр моны.* Д.Булатова

2) Кимү, кими төшү, азаю, кайту, бетә төшү. *Син төнлә, кеше аягы шилгәч тә, казып алырсың, бер искерәк капчык белән бәләкәй чанага салып, тегендә миңа илтерсең, яме.* Ш.Камал. *Мәгәр аның ярсуы-дуамаллануы ике-өч көннән ары бармый, суы да атна-ун көн эчендә шилә, ярларына кайтып төшә ---.* К.Миңлебаев

3) Ябыгу, тартылу. *Ускән саен шилә бу кыз*

**Шилә башлау** Шилүгә таба бару; шилергә тотыну. *Садриев хатынын да күндереп бетерде инде: яшь чакның кадерен бөтен яклап белеп калырга кирәк. Эше дә, теорияләре дә качмас, ә менә хатын, телисеңме-юкмы, шилә дә башлар.* Җ.Юныс

**Шилә төшү** Бераз шилү; тагын да шилү

**ШИМАЛИ** *с. гар. иск.* Төньякка мөнәсәбәтле, төньякка караган, төньяктагы. *Көннәрдән бер көн шул батыр, --- Американы сугышып алу максаты белән, зур сәфәргә чыккан. Алты ай сәфәрдән соң, бик каты сугышлар соңында, Шимали Американы алган.* К.Тинчурин. *Бөек солтаныбыз сезнең, ягъни шимали төрекләренең, Идел-Чулман татарларының ягъни, аянычлы хәлен ишеткән.* А.Гыйләҗев

**ШИМАЛЬ** *и. гар. иск.* Төньяк. *Шуннан соң карчык әйтә: «Мин җилләр әнкәсе булам, минем шималь тарафыннан искән улым бик усал».* Әкият. *Шималь белән безнең авыл арасында котыпның салкын һавасын тоткарлап калырлык бер генә дә тау кисәге юк.* М.Мәһдиев

**ШИМБӘ** *и. фар.* Атнаның якшәмбе белән җомга арасындагы алтынчы көне. *Феня һәр шимбәдә, шәһәр күчтәнәче төяп, авылга кайтып йөрде ---.* М.Мәһдиев. *Күпчелек кешеләр ял көне яга мунчаны, ә без шимбәне кулайрак күрәбез, чөнки икенче көнне --- эшкә дә барасы юк.* Ә.Һидиятов

**ШИМПАНЗЕ** *и. фр.* Имезүчеләр классы приматлар отрядыннан Көнбатыш һәм Үзәк Африкада төркемнәргә оешып, күбесенчә агач башларында тереклек итүче кешесыман маймыл. *Бүгенге көндәге маймыллар да күптөрле тавыш сигналлары чыгара алалар. Мәсәлән, гориллалар 20 дән артык, шимпанзелар 30 га якын тавыш сигналы чыгара алалар.* Н.Фәттах. *Кошлар, кимерүчеләр һәм бөҗәкләрдән тыш, агач башларында күпсанлы маймыллар – мартышка, шимпанзе һ.б. яши.* Материклар һәм океаннар географиясе

**ШИН** *и. нем.* 1) Ашалмасын һәм тиз тузмасын өчен агач тәгәрмәч тугымына кидерелә торган тимер коршау. *Тау астында тимерчеләр чыңгылдаган тавыш чыгарып чүкеч суга, ат дагалый, тәгәрмәчкә шин тарта.* Г.Бәширов. *Ә бер почмакта шин-коршау сугылмаган көенчә муртая башлаган тәгәрмәч сөялеп тора.* А.Тимергалин

2) Машина, велосипед һ.б.ш.ның тәгәрмәчләрендә һава белән тутырылган баллонга кидерелгән резин коршау. *[Автомобильнең] көпшәк шины ләшперәп төшкән, тәмам бушаган.* А.Шамов. *Шри-Ланкада Советлар Союзының ярдәме белән шин заводы, --- элеватор һ.б. объектлар төзелгән.* М.Мәһдиев. *Радист --- велосипедын да шины тишелгәнгә күрә ташламаган – ул аны үзе тишкән.* З.Фәтхетдинов

3) *мед.* Сынган, җәрәхәтләнгән, тайган яки башкача зарарланган әгъзаларның хәрәкәтсезлеген тәэмин итү өчен каты материалдан эшләнгән җайланма. *Мылтык куян ядрәләре белән корылган булган. Шулай да бер сеңерне зарарлаган, аякны бөгеп булмый. Аңа шин куеп бәйләделәр, үзенә култык таяклары тоттырдылар.* Х.Камалов. *Юл дыңгырдык бит, посёлокка барып җиткәнче, минем имгәнгән аягымны ике кулы белән тотып кайтты Лена. – Ә кем бәйләде, дәвалады? – Шин салу, бәйләү хәтлесен үзем дә беләм инде ---.* М.Маликова

**ШИНЕЛЬ** *и. фр.* Арты бөкләмләп һәм биллек ярдәмендә бил турысын кысып тора торган итеп махсус өлгедә калын сукнодан тегелгән озын чабулы форма пальтосы. *Көн салкын булмаса да, җил дымы шинель аша да үтеп, тәнне чиркандыра.* Х.Камалов. *Соңгы теләге үтәлгән солдатканың арык кулы шинель җиңенә чытырдатып ябышкан килеш калды.* М.Мәһдиев

**ШИНЕЛЬЛЕ** *с.* **1.** Өстенә шинель кигән. *Чернышевский урамы буйлап Кремльгә таба кызылармеецлар колоннасы килә. Барысы да яңа шинельле, пилоткалы.* Г.Әпсәләмов. *Фаягөл --- базар капкасыннан килеп кергән шинельле солдатка төбәлде.* А.Әхмәтҗанова

**2.** *и. мәгъ.* Шинель кигән кеше. *Ишек шарт итеп ачыла, шарт итеп ябыла. Тунлылар, бишмәтлеләр, шинельлеләр керәләр дә, аякларындагы карны кагып, эчкә узалар ---.* И.Гази. *Укытучылар барысы да фронттан, арада соры шинельлеләр кара шинельледән күбрәк иде.* М.Мәһдиев

**ШИНЕЛЬЛЕК** *с.* **1.** 1) Шинель тегәргә китә торган, шинель тегәр өчен, шинельгә яраклы. *Шинельлек сукно. Шинельлек тукыма*

2) Шинель тегәргә җитәрлек. *Планнан тыш сәгать саен бер шинельлек сукно туку. Өч шинельлек сукно*

**2.** *и. мәгъ.* Шинель тегәргә яраклы материя. *Кибеткә шинельлекләр кайткан. Шинельлек сатып алу*

**ШИНКАРЬ** *и. пол. иск.* 1) Шинок хуҗасы, шинок тотучы

2) Яшерен рәвештә исерткеч эчемлекләр әзерләүче һәм шуның белән сату итүче кеше. *[Хафизның], Дәүләкән шинкарьларына барып, марҗалар белән көмешкә эчеп утыруы турында да сүзләр чыккан иде.* Ә.Еники. *Кышкы үтә салкын көннәрнең берсендә --- «яхшы гына» салып алгач, ул кичкырын туры алашасын җигеп кайтырга чыга. Юл уңае Иске Печмәндәге шинкарьда тагын бер чәкүшкәне бушатып ала һәм --- юлың дәвам итә.* К.Фасиев

**ШИНЛА́У** *ф.* Шин (*1 мәгъ.*) сугу; шин кидерү. *Башта вак-төяктән генә керешә бу: кемгәдер урак тешәүләде, чалгы тапады, кайрады... Соңрак ишек тоткалары, капка келәләре ясый башлады. Соңрак инде ат дагалау, арба көпчәкләре шинлау ---.* М.Хәсәнов

**ШИНЛЫ** *с.* Шины булган, шин кидерелгән. *Резин шинлы йомшак фаэтонга утырып барганда, бөтенләй калын киез итек киеп барган кеби буласың.* Г.Тукай. *Кайтышлый Казандагы Сорочий базарына кергән дә коточкыч киң мөгезле, туфракта әллә ниткән эзләр калдыра торган шинлы немец велосипеды сатып алган.* М.Мәһдиев

**ШИНОК** *и. пол. иск.* Революциягә кадәр Россиянең көньяк губернияләрендә, Украинада исерткеч эчемлекләрне чәркә белән сату, эчү урыны; кабак

**ШИНШИ́ЛЛА** *и. исп. зоол.* Кимерүчеләр отрядыннан озын, куе, көмештәй соры мехлы, озын койрыклы, тиенгә охшаган Көньяк Америка җәнлеге. *Кимерүче хайваннардан шиншилла үзенең затлы мехы белән аерылып тора.* Материклар һәм океаннар географиясе. *Әгәр бу тиреләр канәгатьләндермәсә, актөлке, кондыз, шиншилла тиресеннән тегелгәнне алырга мөмкин.* Безнең гәҗит

**ШИНЬОН** *и. фр.* Өстәлмә парик чәч куеп ясалган хатын-кыз причёскасы һәм өстәлмә парик чәч үзе. *Иртән маңгаен каплап торган чәчләре арттан эләктереп куелган булса, хәзер алар баш түбәсенә өелеп, үрелгән шиньон белән уратып алынган, аның берничә җиренә ялтыравык брошка кадалган.* Т.Әйди. *Чем кара күзле, чибәр генә йөзле кыз иде бу. Күз тирәләренә шәмәхә иңдергән, баш түбәсендә күпертеп салган чәч, әллә шиньон, әллә парик, белмәссең.* Казан утлары

**ШИҢГӘК** *с. диал.* 1) Тиз шиңә торган; шиңә башлаган. *Шиңгән үләнне ашаган мал шиңгәк булыр.* Мәкаль

2) Хәлсез, буыннарында хәле булмаган; чирләшкә

**ШИҢДЕРҮ** *ф.* 1*) йокл. юн. к.* **шиңү**. *Шул көнне мин, кырау шиңдергән иксез-чиксез бәрәңге басуларыннан таралган затлы искә исереп, бу бәхеткә ирешә алмаган шәһәр малайларын --- кызгандым.* М.Мәһдиев. *Кояш инде китеп бара иде, Әллә нинди суык җил өреп. Афәт булып гөлбакчамда йөреп, Чәчәкләрне китте шиңдереп.* К.Булатова

2) Зур булып, кабарып торган әйберне кечерәйтү, күләмен киметү. *Ә хәзер бераз ятып торыйм әле мин. Корсак шиңдерим.* Ә.Сафиуллин

3) *күч.* Киметү, кечерәйтү, элеккеге көчен югалттыру. *Рамилә куллары аша тапшырылган биотоклардан баш калкыта башлаган гайрәтен шиңдерергә шушы сүз җитте.* Н.Әхмәдиев

**Шиңдерә төшү** Бераз, берникадәр шиңдерү. *Ләкин нибары бер ел мәктәптә эшләү кикригемне шиңдерә төште.* М.Яһүдин

**Шиңдерә язу** Чак кына шиңдерми калу. *Менә монысы инде әле бая гына тырпайган кикрикне шиңдерә язды.* Ф.Баттал

**Шиңдереп бару** Аз-азлап, акрынлап шиңдерү. *Хәлимәнең өч кешегә булган мәхәббәте дә әнә шулай аерылгысыз бергә үрелгән --- һәм инде сагыш җилләре ул катлаулы тойгыларны киптереп, шиңдереп бара, гомернең азагына якынаюын искәртә иде.* Ф.Садриев

**Шиңдереп бетерү** Тәмам, бөтенләй шиңдерү. *Бетердем шиңдереп төрле гүзәл чәчкәмне барсын да Явыз тәкъдир, каты тәкъдир, суык тәкъдирем астында.* Г.Тукай

**Шиңдереп тору** Әле, хәзер шиңдерү; вакытлыча шиңдерү. *Болгар иле ярты Азияне яулап алган рәхимсез һәм дәһшәтле дошман һөҗүмен үз кукрәге белән каршылап, --- илбасарлык гайрәтен шиңдереп тора...* М.Мәхмүтов

**ШИҢҮ** *ф.* 1) Яңгыр булмау, су сипмәү, дым җитмәү сәбәпле үсемлекләр сусыллыгын, тулылыгын югалту, сулу. *Гөлләрем шиңәр инде, Кемнәр су сибәр инде.* И.Юзеев. *Корылык килсә, озак вакытлар яңгыр тамчысы төшмәсә, иң элек декоратив үсемлекләр сула. Вакытында тәрбия күрсәтмәсәң, шәлперәеп төшә, шиңәләр бичаракайлар.* Р.Низами

2) Зур булып, кабарып торган әйбер кечерәю, күләме киму; шилү. *Нәкъ шул вакыт факир аның авызына үзенең сыбызгысы белән бик каты суга. Аптырап калган кобра беразга капюшонын шиңдерә һәм тагын һөҗүм итә.* М.Мәһдиев. *Ни телисең, чибәр туташ, теләгеңне сыра күбеге шиңгәнче үтим.* Ф.Яруллин

3) *күч.* Сулу, яшьлек төсен, тулылыгын югалту. *Зәйнәп егылган урыныннан тормады. Озын кышкы төннәр тынычсыз ютәл, авыр саташулар белән үтте. Аның күз төпләре күгәрде, йөзләре шиңде.* Һ.Такташ. *Сусыз корган чияләрдәй, Чәчәк атмый шиңдем мин.* Т.Гыйззәт

4) *күч.* Берникадәр киму яки бетү. *– Больница бинасын колхоз исәбенә төзергә кирәк булачак, – ди. Ул шулай дигәч, гайрәте шиңде председательләрнең.* В.Нуруллин. *Җиңги дигәне дә әле аңардан биш-алты яшькә генә олырак хатын лабаса, абыйсы белән дә озак яшәп кала алмадылар, чибәрлеге шиңеп өлгермәгән, кызларына бирешкесез иде.* Я.Зәнкиев

5) *күч.* Омтылышлар, теләкләр һ.б.ш. юкка чыга башлау, тынычлану, хистойгылар басылу, сүрелү. *Читләрнең сиңа кызыгып та ымсынып күз ташлавы ир хатыны чагында гына. Озакка бармас андый ымсынулар. Бик тиз шиңәрсең.* К.Миңлебаев. *Медицинаны белмәгән килеш кызлар белән чуалсаң, бик тиз шиңәр мәхәббәтең, дип, Зәет кайнар бәхәскә кереп китә.* Ф.Баттал

6) *күч.* Әрәм булу, үтеп китү, бетү. *[Сәхипҗамал:] Безнең балалык кайгыда шиңде шул.* А.Әхмәт

**Шиңә бару** Торган саен шиңү. *Мөдир әлеге кинаягә игътибар итмәгән төсле кыланса да, тантаналы, җиңүчән, сугышчан рухының җылыга эләккән боздай шиңә баруын сиземләве кыен түгел иде.* Т.Галиуллин. *Синсез боегам, суга сусаган чәчкә кебек шиңә барам.* З.Мәхмүди

**Шиңә башлау** Шиңүгә таба бару; шиңәргә тотыну. *– Бозаулаган сыерның эче шулай юан буламы? – Дүрт-биш көн шулай булып тора, аннары гына шиңә башлый, – диде Әдәс бик белдекле кыяфәттә.* Ф.Садриев. *Чалмабашлар шиңә башлауга, тирә-якка нур бөркеп, сапсары лилияләр чәчәк ата.* Р.Хәбибуллина

**Шиңә төшү** Аз гына шиңү; тагын да шиңү. *Шактый киң җилкәсе шиңә төшкән, аркасы бөкрәя башлаган кебек тоелды.* Л.Ихсанова. *Йокысы тәмам туйган, йөзендәге кызыллыгы бераз шиңә төшкән Белугин, ---мыштым гына атлап --- Һарун янына чыкты ---.* Н.Фәттах

**Шиңеп бару** *к.* **шиңә башлау**. *Дәрес, баштагы көннәрдә бераз гайрәт чәчтеләр, хәзер инде куыклары шиңеп бара, Мәскәүгә якын да җибәрмиләр.* Т.Гыйззәт. *Чәчәкләрем инде шиңеп бара, ә алучы юк.* Ф.Яруллин

**Шиңеп бетү** Тулысынча шиңү. *Чәчәкләр шиңеп беткәнче сатып кайтыйк.* Г.Рәхим. *Куык шиңеп беткәч, барча халык Ялмавыз карачкысы артында торган симез түгәрәк гәүдәле җантыкны күреп алды.* Р.Батулла

**Шиңеп калу** Берәр тәэсирдән соң шиңгән хәлгә килү. *Кайнар уйлар, хыялый, тиле уйлар, тишелгән куык сыман, кинәт шиңеп калды.* Н.Фәттах. *Гази кинәт кенә шиңеп калгандай булды, авыз эченнән генә мыгырданып куйды.* М.Хәсәнов

**Шиңеп тору** Хәзер шиңү; шиңгән хәлдә булу

**Шиңеп төшү** Кинәт шиңү. *Ләйлә күз алдында шәлперәеп, шиңеп төште.* Ф.Бәйрәмова. *Матур гына үсеп утырган җирләреннән чәчәкләр үлә башлады: кайсылары кара көеп чыга, ә кайберләре шиңеп төшә.* А.Мансуров

**ШИРБӘТ** *и. гар.* **1.** 1) Бал кушып әзерләнгән татлы су. *Аннан дүрт-биш*

*урынга бәлеш килде. Аннан ширбәт, һинд чәенең хуш исенә баш әйләнде, чәй янына кәрәзле бал куелды ---.* М.Мәһдиев. *Йотлыга-йотлыга эчте. Үз гомеренә беренче мәртәбә су тәмен тойды ул. Гел ширбәт инде менә.* Ф.Җамалетдинова

2) Җимеш, кофе, шоколад, чикләвек төше катнашмасына шикәр кушып әзерләнгән куе масса рәвешендәге татлы ашамлык. *Ширбәт белән чәй эчү*

3) Чәчәк балы, нектар. *Каяндыр шөпшәләр, бал кортлары килеп җитте. Ширбәт эчәләр.* Ш.Галиев. *Тын юлларына кадәр буып, бар дөньяны бал исе басты, моңарчы планын үти алмаган бал кортлары төнлә дә --- ширбәт ташыды.* А.Хәлим

4) Җиләк-җимешне әчетеп әзерләнгән исерткеч эчемлек; шәраб. *Менә нинди татлы, менә нинди ләззәтле син. Көчле ширбәт шикелле башны әйләндерәсең, йөрәкне җилкендерәсең.* Ф.Яруллин. *Сихерче Лахсай --- кымыз эчеп кызарып, буза эчеп бузарып, ширбәт эчеп шәбәреп йөрде дә үр өстенә чатыр корган хуҗасы Бузмах янына кайтып китте.* Р.Батулла

5) *күч.* Ләззәт, кинәнеч һәм рәхәтлек хисе. *Бик күп эчкәнмен мәхәббәт ширбәтен.* М.Гафури

**2.** *с. мәгъ. күч.* Татлы, ягымлы, күңелгә ятышлы, күңел кабул итә торган. *Турылыклы, түзем яшь киленнәр, Ширбәт сүзле илем кызлары! Без кайтырбыз җиңү юлларыннан.* Ш.Маннур

◊ **Ширбәт ае** *к.* **ширбәтле ай**. *Яшьләр яратышып кавышкан, ширбәт аен уздырган, дөнья корган икән.* Г.Хөсәенов. *– Ринат бергә булган мизгелләрне онытылмаслык итеп ясый. Ширбәт аебыз да истә калырлык булыр дип өметләнәм, – дип, шатлыклы елмайды яшь кәләш.* Э.Сәлахова

**ШИРБӘТЛӘ́Ү** *ф.* Шикәр яисә бал өстәү, татлы, ширбәтле итү. *Он-май белән әвәләгән, Бал-ширбәтләп әлбәләгән кә-лә-вә!* Н.Исәнбәт

**ШИРБӘТЛЕ** *с.* 1) Татлы, баллы. *Үги әти һаман сөйли: – Анда әле карбыз да үсә, – ди. – Беләсеңме, үзе түмтүгәрәк, алам дисәң – кочакка сыймый. Үзе ширбәтле, татлы, эченә бал салганнар диярсең.* Н.Дәүли. *[Тукран] Тукый-чукый, Каен тиште Һәм ширбәтле Суын эчте.* Ш.Галиев

2) *күч.* Ләззәт, кинәнеч һәм рәхәтлек хисе бирә торган. *Тик сиздем татлы, ширбәтле Ут кебек иреннәрен.* Ә.Ерикәй. *Бәйрәм ашы кара-каршы..., кыскасы, кочагына кердем сылукайның. Кайнар, ширбәтле...* М.Әмирханов

3) *күч.* Берәр кешегә ошый торган; күңел кабул итә торган. *Бәхтияр, бу шаяртуны өнәмәгәндәй: – Ә абыйсы синнән күзен алмады, нинди генә ширбәтле сүзләр әйтмәде, – дип, борын астыннан мыгырдап куйды.* С.Сабиров. *Ләкин тик син сихәт бирдең, Җанымда җәннәт ачтың, Ширбәтле сүзләрең белән Газапларымны бастың.* Р.Зәйдулла

◊ **Ширбәтле ай** Өйләнеп, егет кыз куенына кергән беренче ай. *Ниһаять, ширбәтле ай узды шикелле. Ике атна кияүләп йөргәннән соң, Мостафин Наҗиясен үзенә алып кайтты.* Ә.Еники. *Лейтенант сизеп алды: кияү турында сөйләшү Мурлыкинага бер дә ошамый. – Алай булгач, Найла Владимировна, мин сезне ширбәтле аегыз белән котлыйм. Хәзер туй сәяхәтенә җыенасыздыр инде?* З.Фәтхетдинов

**ШИРИН** *с. фар. иск.* Татлы, баллы, ширбәтле. *Шикәрдән ширин, балдан татлы тел тибрәтеп әйткән сүзләрең.* Җыр. *Бу кәйфияттә кибет бик нәфис һәйбәт, вә һәм хәлвә бик нәфис ширин вә татлы булганга күрә, хаҗәт булмаган кешеләр дә килеп алырлар иде.* К.Насыйри. *Сагышларга дәва ширин сүзең дә.* Дәрдемәнд

**ШИРКӘТ** *и. гар.* Сәнәгать, сәүдә һ.б. эшләрдә бергәләп эш итү максаты белән тигез хокуклы әгъзалардан оешкан берләшмә. *Ул һәрвакыт йөрү белән бәйләнгән сәүдәне ярата иде. Шуңа күрә кибет ачмады, берниндн ширкәткә кушылмады, ә искечә ялгыз башы йөреп сату итәргә тотынды.* Ә.Еники. *--- тоттык та җыйнаулашып без «Каләм батырлары» исемле тату гына, күркәм генә бакчачылар ширкәте төзеп җибәрдек.* А.Гыйләҗев

**ШИРКӘТЧЕ** *и.* Теге яки бу ширкәттә әгъза булып торучы, ширкәттә катнашучы. *Әтиләре Әхмәтҗанның ширкәтчесе булганлыктан, яшь кунаклар хөрмәтенә җиңел кулдан тиз генә табын әзерләделәр.* С.Сабиров. *Төштән соң дала ягыннан зур гына ат көтүе якынлашты. Ул утлап килде, килде дә, юлны аркылы чыгып, туп-туры ширкәтчеләр кырына басып керде.* Т.Әйди

**ШИРЛЕК** *и. диал.* Шуклык, чаялык

**ШИРЛЕКЛЕ** *с. диал.* 1) Шук, шаян. *Ширлекле бала*

2) Шаяртулы, шаяртуны эченә алган. *– Мин үзем туганнан бирле бисфартийни кеше булганлыктан, ялгыш сүзләр ычкындырып ташлаган булсам, гафу иткәйсезләр... – Барысы да ширлекле тавыш белән көлешеп алдылар.* Ш.Маннур

**ШИ́РМА** *и. нем.* 1) Кирәкмәгәндә җыеп куярлык итеп эшләнгән, рамга тарттырылган материя яки кәгазьдән гыйбарәт, аерып, бүлеп яки ышыклап тора торган җайланма. *Ул арада Нәфисә, теге яктан ширма чыгарып, Давытка кәнәфидә, мендәрләр, йомшак юрганнар эчендә югалырлык итеп, ятарга урын әзерләде.* Г.Ибраһимов. *Шакмаклы зур ширма белән бүлеп алынган бу почмакка бер дә аяк басканым юк иде.* С.Сабиров

2) *күч.* Яман, тыелган эшләрне каплау яки качып, яшеренеп эшләү өчен файдаланыла торган нәрсә. *Моннан инде Ишморатовның Коръән хәрефләре турында кайгыртуы бер ширма гына икәнлеге аңлашыла.* М.Мәһдиев. *– Министр аларның икесенә дә каты шелтә белдергән. Боерыгының бер нөсхәсен күрсәтә алабыз. – Кирәкми, – диде Ибраһимов, кырысланып, –укыдым мин ул нөсхәгезне. Ширма бу, күз буяу.* М.Насыйбуллин

◊ **Ширма арты** Тормышның, яшәешнең һәрбер кешегә дә күренеп тормаган, яшерен, интим яклары. *[Кариев] байлар, муллалар ролен башкарганда, аларның тышкы кыяфәт һәм кыланышларыннан гына көлү түгел, алар тормышының ширма артын сатира калыбында ача белде.* И.Рәмиев

**ШИФА** *и. гар.* 1) Дәва булу, савыктыру, терелтү үзлеге. *Табибка ихлас күңелдән ышанган кешегә генә дәвалауның шифасы тия.* М.Маликова

2) Саулык-сәламәтлек өчен файдалы тәэсир, сихәт, файда; савыктыру, терелтү көче. *Кулларымны канат итеп очам, Нурлы кояш үбә бит очымнан, Җемелдәшә алмазлардай чыклар, Таң кояшы җанга шифа, ә чык – сихәт.* Г.Галиева. *Була шундый хасталар, ни генә кыландырсаң да, бөтен эшең гел кирегә генә китеп тора, бер дәва да шифа бирми.* М.Маликова

3) Дәва, дару. *Энесе дә Истанбулда табиб буларак эшләде, байтак татар аңарга йөреп шифа табарга тырыша иде.* С.Ибраһимова. *Әгәр дә берәр сырхау вә хәстәлеккә калган адәм баласы үзенә шифа эзләсә, ул иң элек «Фатиха» сүрәсен укыр, чөнки бу сүрәгә барлык авырулардан дәва салынган булыр, аннан соң «Колһуаллаһ»ны укысын.* Ф.Яхин

4) *куч.* Эч пошу, күңел төшенкелеге һ.б.ш. борчуларны җиңелрәк үткәрү яисә шул халәтне бераз җиңеләйтү чарасы, әмәл. *Тик күңел нахак сүзгә бик нык рәнҗегән иде, гарәп хәрефләре белән тулган кәгазь күңел ярасына шифа була алмады.* М.Мәһдиев. *Аның адымнарын, тавышын ишетү, аның кулыннан ризык кабу, күздәге һәм кулдагы бәйләвечне алыштырганда аның бармаклары җылысын тою үлеп барган җанга, әкияттәге тереклек суы кебек, шифа бирә иде.* М.Маликова. *Синең тавыш җанга шифа, Дәвалый йөрәкләрне.* З.Хөснияр

◊ **Шифалы су** Эчемлек, аракы. *Үзләре алып килгән шифалы суны берәр рюмка күтәргәч кенә, бәлешне бик әйбәтләп «ура» башладылар.* Ә.Еники

**ШИФА ЙОРТЫ** *и. к.* **шифаханә**. *Туган җирләр һәм биләүдән чыгып Тәгәрәшеп үскән куышлар Җитмеш төрле чирдән йола торган Шифа йорты күк бит ул, дуслар.* Ш.Маннур. *Истанбулда төрле районнарда утызлап автомашинага ут төртелеп яндырылды, ике шифа йортына бомба ташланды.* Ә.Ибраһимова

**ШИФАЛЫ** *с.* 1) Савыктыргыч, терелтә, сәламәтләндерә торган, шифасы булган, сихәтле. *Килгән юлдан кайтуны өнәмичә, яз саен аларга шифалы суын озак саклаучы яр асты каены янынннан, ермак буйлап атлады.* К.Тимбикова. *Ә Рәшидәнен җанына күптән, шактый еллар буе шифалы яңгырлар яуганы юк иде шул инде.* М.Маликова. *Моның өстенә кулы җиңел, уколны йомшак ясый, карашы шифалы дигән даны да тарала башлады.* Ф.Бәйрәмова // Саулык-сәламәтлек өчен файдалы. *Ә кышын Алабуга белән Затон арасындагы Олы Бор һәм Кече Бор дип йөртелә торган урманнарда нарат агачларының шифалы һавасын сулап чаңгыда йөрүе үзе бер ләззәт, тәнгә сихәтлек иде.* Р.Кәрами

2) Дару ясау яисә дәвалау өчен кулланыла торган. --- *әнисе Гайниҗамал апа тырыша инде тырышуын. Үзләренең сыеры иртә буаз булганлыктан инде күптән ташланса да, каяндыр табып, сөтен-каймагын да, мәтрүшкәсен дә, тагын әллә нинди шифалы үләннәр дә кайнатып эчертә.* В.Нуруллин. *Берәүнең таныш умартачысы, шифалы үсемлекләрне балда-майда кайнатып, бик шәп дару ясый икән...* М.Маликова

**ШИФАЛЫЛЫК** *и.* Шифалы булу сыйфаты. *Өмете акланмады, энҗедәй су бака шәлләре белән томаланып беткән черек улактан агып ята. Ул үзенең изгелеген дә, шифалылыгын да күптән җуйган-оныткан төсле.* К.Тимбикова. *Ул көн дә дүртәр-бишәр операция ясаучы Марсель Васыйл улының сабырлыгына, ягымлылыгына, кулларының шифалылыгына исләр китәрлек.* Ватаным Татарстан

**ШИФАХАНӘ** *и. гар.-фар.* Авыруларны дәвалау, савыктыру йортларының гомуми атамасы. *Шифаханәнең авыруларны кабул итү бүлмәсендәге ак җәймә җәелгән ятагына китереп салгач, Рәфис бермәлне Гөлфинурның тагын да аксылланып киткән чыраена --- карап торды.* А.Вергазов. *Гаиләсе белән барып ял итәр өчен, шифаханәгә юллама бирделәр.* А.Нәҗми

**ШИФАҺӘН** *рәв. гар. иск.* Телдән, әйтеп, сөйләп. *Әллә шифаһән сөйләүчеләр булып та, язып алучылар булмыйча, шул шигырьләр шагыйрьләре белән бергә кабергә күмелдеме?* Г.Тукай

**ШИФАҺИ** *с. гар. иск.* Телдән сөйләнгән. *«Кәләпүшче кыз» тугрысында шифаһи һәм тәхрирән бик күп тәкъризатлар алсам да, берсен дә китабыма дәрҗ кылмадым.* Г.Исхакый. *Инде Ибраһимның хәләл җефете Нәфисә Әмирхания хакында да берничә сүз әйтик. Шунысы бар: безгә килеп ирешкән шифаһи мәгълүматлар аны, кызганычка каршы, күбрәк тискәре яктан сыйфатлый.* Р.Әмирхан

**ШИ́ФЕР** *и. нем.* **1.** 1) Кара яки соры төстәге балчыклы сланец. *Шифер чыгару*

2) Шундый сланецтан яки асбест белән цементтан пресслап ясалган плитә формасындагы төзү материалы. *Рәфис --- урталай ярылган юан бүрәнәләрдән салынып, түбәсе соры шифер белән ябылган терлекчеләр йортын карап чыгарга булды.* А.Вергазов. *Микола абый әтигә колхозы өчен кадак, шифер, түбә калае юклыктан зарланып ала.* А.Хәсәнов

**2.** *с. мәгъ.* Шул материалдан эшләнгән. *Кырлар инде буш калган, ап-ак шифер түбәле фермалар өстеннән җылы пар күтәрелә.* М.Мәһдиев. *Ул үзенең булачак йортының сырлы шифер түбәсен күрде, тырпаеп утырган кызыл морҗасын күрде, бакча эчендә алмалар, карлыганнар күрде...* Н.Фәттах

**ШИ́ФЕРЛЫ** *с.* 1) Шифер (*1 мәгъ.*) катнаш. *Тау битенең түбән өлешендә шиферлы (сланец кисәкләреннән торган), культуралашкан туфрак ясалган.* Җир һәм туфрак

2) Шифер (*2 мәгъ.*) белән япкан. *Алтыпочмаклы ярым иске йортның шиферлы түбә башында кояш астында уңып төсен югалткан кызыл әләм җилферди.* Х.Ибраһим. *Болай, бер караганда, һич тә тормаслык йортлар түгел: кайсы кирпеч, кайсы плитәләрдән эшләнгән таш стенасы, соры шиферлы түбәсе – бар да урынында, йорт тирәсенә --- сап-сары нарат такталарыннан коймасы да корылган.* А.Вергазов

**ШИФОН** *и. фр.* **1.** Бик юка киҗемамык яки ефәк тукыма. *Түрдәге кечкенә сәхнәгә төрек кызы йөгереп чыкты: күкрәгендә алсу бюстгальтер, кара шифонга кызыл розалар төшкән итәк кигән.* Р.Зәйдулла. *Итәкне, җиң очларын һ.б. детальләрне дә, үтүкләгәндә, шулай ук серкәле су белән чылатырга тәкъдим ителә, чөнки кайбер тукымалар сыланып тормаучан була, мәсәлән, крепдешин, шифон һ.б.* Йорт эшләре

**2.** *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән, ясалган. *Өстенә яңа гына тектергән шифон күлмәген кигән иде.* Р.Рахман. *Баягы шифон тасмадан бөкләмнәр ясый-ясый, чәчәк рәвешенә китерәбез ---.* Сөембикә

**ШИФОНЬЕР** *и. фр.* Кием шкафы, гардероб. *Өй эше шыплап тутырылган комиссия кибетен хәтерләтә: почмак саен шифоньер, төрле-төрле дәү көзгеләр, --- җиз калайлар белән бизәкләнгән олы сандыклар.* А.Гыйләҗев. *Ул --- иркен генә бүлмәсендә сары фанердан гына булса да зур көзгеле шифоньер бастырып куйган икән.* А.Тимергалин

**ШИФР** *и. фр.* 1) Яшерен язу өчен шартлы билгеләр системасы. *Гәрәй --- Габдулла абзый аркылы яшерен шифр белән Булатка язган.* Г.Ибраһимов. *Хат яшерен тамгалар ярдәмендә, ягъни шифр белән язылган.* Р.Мөхәммәдиев

2) Китапханә, архивларда китап яки кульъязманың кайда, нинди урында саклануын белдерә торган хәрефле яки цифрлы регистрацион шартлы билгеләр. *Бер шигъри кульъязмасының фрагменты Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә 39 нчы коллекция, 2308 нче шифр астында саклана.* А.Гайнетдинов

3) Нинди дә булса яшерен документ, махсус билгеләнешле һ.б.ларны тамгалау өчен билге. *«Секретно» дигән шифр белән патша хәзрәтләре сараеның камергеры губернатор Стрижевский үзенең жандарм идарәсенә күрсәтмә*

*бирә: Фатих Әмирханны тикшерегез әле ---.* М.Мәһдиев. *Барлык Оператив идарә дә, бертөрле генә шартлы төсләр кулланып, үзенең билгеләрен хәрби хәрәкәтләргә билгеләнгән шартлы шифрлар куя ---.* З.Зәйнуллин. *Проект шифры. Завод шифры*

4) Мәгънәсе билгеле кешеләр өчен генә аңлаешлы булган яшерен хәбәр. *Бу әле күптән түгел генә, «әтигә солдаттагы энесеннән хат килде», я булмаса «әти балыкка барырга чакырды» дигән шифрлар китереп йөрүче маякчы кызы Илсөяр иде.* Г.Гобәй

**ШИ́ФРЛАУ** I *ф.* 1) Шифр (*1 мәгъ.*) белән язу. *Монда нидер шифрлап язылган.* А.Тимергалин. *Аларның шифрлап җибәрелгән һәм без кулга төшергән хаты бик озак, төн буе тырышып ачыклаганнан соң, бик әйбәт нәтиҗә бирде.* Р.Мөхәммәдиев

2) Шифр (*2 мәгъ.*) сугу

**ШИ́ФРЛАУ** II *и.* 1) Мәгълүматны билгеле код нигезендә аңламаслык итеп язу; кодлау. *Мәшәкатьле чакта вакыт дигәнең аргамакка атланып чаба: шифрлау бүлегеннән җибәрелгән белешмә күптән килгән икән.* Ш.Рәкыйпов. *Роскомнадзор һәм ФСБ вәкилләре Телеграмның шифрлау ачкычларын күрсәтергә таләмәве террорчыларга ярдәм итәргә, җәмгыятькә куркыныч тудырырга мөмкин дип белдергән.* Кәеф ничек?

2) Шифр сугу эше

**ШИ́ФРЛЫ** *с.* 1) Шифр белән язылган, яшерен. *Шул урында партия лидеры аны, зур ялганда тоткан сыман, бүлдерергә кирәк тапты: – Социализм идеяләрен тарату өчен, шифрлы язу кирәк булдымы?!* Р.Мөхәммәдиев. *Ленин шул ук көнне Фрунзега шифрлы телеграмма җибәрде: «Оренбурның нинди кыен хәлдә калганын беләсезме?»* Ф.Сафин

2) Шифр сугылган. *«Эчке куллану өчен» шифрлы документ*

**ШИФРОГРА́ММА** *и. фр.-гр.* Шифр белән язылган телеграмма, радиограмма, телефонограмма. *Аппаратта әллә ниткән «помеха»лар бар иде, шуларның берсендә «бугазы» дигән сүз дә ишетелгәч, Әркәшә, тисә тиенгә, тимәсә ботакка дигәндәй, Аллага тапшырып беренче тотылган шифрограмманы ачты.* М.Мәһдиев. *Ә Талипчик-Салыпчык икенче көнне үк районга шифрограмма – телеграмма җибәргән.* М.Юныс

**ШИФЫРТ** *с. сөйл.* **1.** Купшы киенгән, көяз. *Юл буена казык күк кагып киттек шифырт егетне!* А.Гыйләҗев. *Мине... үзебезнең якта шундый шифырт егетләр бармы икән, «Зәкәрҗан мәктәбе» әле дә яшиме икән дигән фикер борчый.* М.Мәһдиев

**2.** *рәв. мәгъ.* Көязләнеп, кыланып. *Гатаның министрлык баскычы төбенә шәп итеп килеп, шифырт туктыйсы килде.* М.Мәһдиев

**ШИ́ХТА** *и. нем. махс.* Махсус агрегатларда металл эретү яки химик эшкәртүгә китә торган руда, металл, ташкүмер, шлак, флюс һ.б.ның катнашмасы. *Бары тик өстә, югарыгы катта гына, дөбер-шатыр китереп, вагранкага яңадан шихта тутыра башлаган тавыш ишетелә...* М.Хәсәнов. *Пароходчылыкның утыз биш мең тонна керешле ике балкеры без салып биргән металлургия комбинатына шихта ташый.* М.Юныс

**ШИШ** *кис. сөйл.* 1) *к.* **чыш** II. *Мин килмәгән булсам, барыбер бүтән бер хатын-кызны алып килер иде ул. Шиш менә аңар бу юлы!* В.Нуруллин. *Сез бит, авылдашлар, гомер буе колхоз складлары аркылы ашап яшәдегез, үзегез, балаларыгыз шушыннан туенып торды. Ә хәзер шиш. Складта уксустан башка берни дә калмады!* Х.Ибраһим

2) Кукиш, кәҗә тоягы. – *Менә сиңа байлык! – Илгизәр Садыйковка «шиш» күрсәтте.* Р.Сәгъди

**ШИШАРА** *и. фар.* Өйдә төче камырдан пешерелә торган вак күмәч. *Аларның берсе кулына зур поднос белән чәкчәк күтәргән, ә икенчесе, ак салфеткага салып, шишара (пич төбенә салынган кечкенә ипи) тоткан.* Э.Мөэминова. *Шишара пешерү өчен, гади төче камыр басыла.* Халык ашлары // Ипи камырыннан махсус кечкенә итеп пешерелгән ризык. *Байтактан соң ипи пешеп чыкты, өйгә тәмле ис тулды. Өстенә тоз сибеп тыккан теге бәләкәй ипиләре белән шишарасы бигрәк тә матур булып, кызарып пешкән иде түтәйнең.* Ш.Маннур. *Күк йөзендә ай кызарып тора, тирәюне алсу төстә, үзе ипи шишарасы кебек яссырак.* Р.Кәрами

**ШИШӘК** *и. фар. тар.* Борынгы сугышчылар киеп йөргән очлы баш киеме. *Алтын Урда гаскәрендә кулланылган корал төрләрен түбәндәгечә күз алдына китерергә мөмкин: кальга алу җайланмасы, беренче утлы корал, шишәк, көбә, калкан, сөңге, ук-җәя, кылыч, хәнҗәр, айбалта, озын саплы балта, чукмар, кистән...* Р.Фәхретдинов

**ШИ́ШКА** *и. рус сөйл. ирон.* Югары дәрәҗәле, сүзе үтүчән, зур кеше. *Бер борылыштан кинәт кенә килеп чыкты. Зур чиннар гына кия торган зәңгәрсу-күксел шинельдән, шундый ук тышлы мех бүректән. Ниндидер «шишка» булырга охшый.* Х.Камалов. *Ул, янәсе, өлкә комитетының бер «шишкасы», төрмә шартларында да түрәлек кыяфәтен саклый белә, теләсә кем белән вакланырга тиеш түгел.* С.Поварисов

**ШКАЛА** *и. лат.* 1) Үлчәү приборындагы сызыкчалар һәм цифрлар, шулай ук тигез өлешләргә бүленеп, цифрлар куелган линейка яки прибордагы циферблат. *Радиоалгыч янына килеп, аның шкалаларын карады, капкачын ачып япты.* Г.Мөхәммәтшин. *Бу градуслар, гомумән, термометр шкаласындагы билгеләр – тамгалар гына түгел, нефть, мазут, газ, күмер, торф, утын – кыскасы, ягулык ресурслары алар.* М.Зарипов

2) Нинди дә булса зурлыкны үлчәү яки билгеләү өчен алынган саннар системасы. *Сонорлык тавыш (тон) шаудан төрле дәрәҗәдәге өстенлеге белән билгеләнә. Димәк, саңгырауларны бу шкалага кертмәскә дә була, чөнки аларны әйткәндә, тавыш катнашмый.* Ф.Сафиуллина

**ШКА́ЛИК** *и. нем. иск.* 1) 0,06 литр яки 1/200 чиләк күләмендәге аракы, шәраб яки гомумән сыеклык үлчәү берәмлеге

2) *сөйл.* Шул күләмдәге аракы, шәраб шешәсе яки кечкенә стакан. *Казаннан кайткан саен Шаһинур Хәзрәтовның аңа керүе, күчтәнәчкә бер шкалик кына коньяк алуы Габдулланы үтерә дә куя.* Р.Сибат. *Марҗа Солтан алдына бер шкалик аракы белән закуска китереп куйды.* Т.Мөбарәков

**ШКАТУ́ЛКА** *и. пол.* Вак-төяк, гадәттә, кыйммәтле әйберләр саклау өчен туры параллелепипед формасында кечкенә тартмачык; котыйчык. *Тиз генә шкатулка эченнән шактый калын йөзәр сум итеп төргән кәгазь акчаларны кесәсенә йомарлап тыгып, шкатулка төбендә калган берничә кәгазь акча белән шкатулканы Закирга таба суза ---.* Г.Камал. *Фәһим муенсаның матур кызыл шкатулкада торганын белә.* Ф.Садриев. *Шкафның өске тартмасында аның бизәнү әйберләре салынган шкатулка тора иде.* М.Маликова

**ШКАТУР** *и. сөйл.* 1) *к.* **штукатурка**. *Бу өй башка өйләргә караганда карсак, буялмаган, шкатурлары кубып беткән стенасына күмер вә акбур берлән әллә*

*ниләр язып, чобарлап бетерелгән ---.* Г.Ибраһимов

2) *күч.* Кершән-иннек, макияж. *Дөбәрис төрттереп алды: «Шкатур, шкатур, Шкатурлары матур...». Бу такмакның бик нык буянырга яраткан кызларга әйтелүен яхшы белгәнгә, --- кыз да җавапсыз калмады ---.* Р.Кәрами

**ШКАТУРЛА́У** *ф. сөйл.* Штукатурлау. *Тышларын шкатурлап-буяп та җибәргәч, ул зур фин йортлары Вәрәшкә бөтенләй шәһәр төсе бирә башлады.* Ф.Латыйпов. *Урта Азиядән килгән кунаклар, тозсыз җырларын суза-суза, стенаны шкатурлап маташа иделәр...* Ф.Бәллүр

**ШКАТУРЛЫ** *с. сөйл.* Штукатурланган, штукатурка белән сыланган. *[Өйнең] идәне – имән паркет, түшәме шкатурлы, стеналары майлы буяу белән буялган.* Ә.Еники

**ШКАФ** *и. ингл.* Әйберләр саклау өчен эшләнгән ачылмалы ишекле йорт җиһазы. *Ганс шкафтан икмәк кисәген алып килеп, урталайга бүлеп, берсен кире илтеп куя.* А.Алиш. *Гөлфинур --- китаплар шкафының аскы тартмасыннан кәгазь, каләм сабы табып алды ---.* А.Вергазов. *Тик бүген анда көзгеле кием шкафы кукраеп утыра иде.* А.Әхмәтгалиева

**ШКВАЛ** *и. ингл.* 1) Гадәттә, яшенле яңгыр китерә торган тиз үтеп китүчән кискен, көчле җил. *Бик көчле шквалга эләгү. Төнге шквал*

2) *күч.* Бик көчле артиллерия уты; ут давылы, ут өермәсе. *Баш очында камышлар яна, ут шквалы җил кебек үтеп китә, янгын сулышы тыннарны кыса.* Азат хатын

3) Кинәт, кисәк, шактый зур күләмдә, санда, зур көч белән булган нәрсә. *Овацияләр шквалы*

**ШКИВ** *и. голл. тех.* Көч тапшыру каешын яки канатны хәрәкәткә китерә торган киң кысалы тәгәрмәч. *– Кая, туганнар, мине дә кертегез әле арагызга, – диде ул һәм, каеш кидертергә азапланган хатын-кызлар башларын күтәреп караган арада, трактор белән молотилка шкивларын тоташтырып та өлгерде.* Г.Кашапов. *Көлтәне барабанга дөрес тыкмый гына кара, күз ачып йомганчы, барабан тыгылачак һәм шкивны алып ташлаячак.* Р.Зарипов

**ШКИ́ПЕР** *и. голл.* 1) *иск.* Коммерция судносы капитаны

2) Үз двигателе булмаган елга судносы (баржа) командиры. *Баржаның шкиперы, базык гәүдәле, тәбәнәк буйлы егет, башта ышанмый торды.* С.Сабиров. *Офицерлар баржада шкипер каютасы белән янәшә бүлмәне биләделәр.* Ф.Тарханова

3) Зур судноларда палубадагы әйберләр өчен җаваплы кеше. *Наполеонны грек пароходы шпикеры күреп алган. «Суднобызны күселәр басты, шуларны бераз тыймасмы», – дип бездән рөхсәт сорап, шул песине үз корабына алган иде.* А.Хәсәнов

**ШКУ́РНИК** *и. рус гади с.* Бары тик үз мәнфәгатен генә кайгыртып башкаларны авыр хәлгә куючы, үз файдасы турында гына уйлаучы кеше; сатлык җан. *Нахаллар, шкурниклар! Үзләре, кичәге «гөнаһлары»ннан аклану өчен, бөтен дөньяны сатарга әзер булгач та, ахрысы, башкаларны да шулай дип уйлыйлардыр.* Г.Ибраһимов. *Йөзләреннән, киемнәреннән Назимов бу писарьларның барысы да немец түгеллеген бик тиз аңлап алды. Арада чехлар да бар. «Илләрен дошман таптый, ә болар монда СС канцеляриясендә бил бөгеп хезмәт итеп яталар. Шкурниклар!» – дип уйлады ул.* Г.Әпсәләмов

**ШЛАГБА́УМ** *и. нем.* Заставада, тимерьюл аркылы чыгу урыннарында һ.б.ш.да юлны ачу-ябу өчен кулланыла торган махсус киртә. *Шлагбаумнан соң әле берсенә, әле икенчесенә җитеп, часовойларны алыштыра-алыштыра бара торгач, менә иң соңгысына да Ишмәмәт белән икәү генә килеп җиттек.* Ә.Еники. *Имеш, узган кышны ак айгыр чанасы-ние, чанадагы председателе белән бергә тимерьюл шлагбаумы аркылы сикереп чыккан.* М.Маликова

**ШЛАК** *и. нем.* 1) Рудадан металл эреткәндә барлыкка килгән көл, таш һ.б.ш. катнашмалардан гыйбарәт калдык масса. *Ә без менә, газлы төтен ярып, Сыек утлы шлак ташыйбыз.* Ш.Маннур. *Платон --- токымны --- банкага салды, аңа терекөмеш кушты. Уттан озак томмый алды һәм, банканы аударгач, кәгазь өстенә шарчык тәгәрәп килеп төште. Шлак та шактый коелды.* Х.Камалов

2) Каты ягулык яндырудан калган калдык. *Анда [станциядә] әйләнә-тирә кап-кара кисәү, шлак, кара янган фашист эшелоннары, кәкрәеп күккә күтәрелгән рельслар һәм пассажирларга билет сату өчен тактадан әмәлләп куйган бер будка бар.* М.Мәһдиев

3) **шлаклар** *күпл.* Организмда матдәләр алышыну процесслары бозылу нәтиҗәсендә эчке әгъзаларга җыела торган кирәксез кушылмалар. *Моннан ун ел элек пациент Рәхмәтуллинны караучы табиблар төркеменә сәләтле яшь доктор Таңсылу Шәфкатия туташ җитәкче сыйфатында беркетелгәч, авыруның сәламәтлеген саклау белән генә чикләнмичә, аның организмын төрле шлаклардан чистарту һәм тазарту, ягъни физик яктан яшәртү буенча тәҗрибәләр алып барыла башлый.* А.Тимергалин. *Җиләктәге пектин һәм целлюлоза организмдагы шлакларны --- чыгара.* Мәдәни җомга

**ШЛАКЛЫ** *с.* Шлак кушылган, шлак белән аралашкан, составында шлак булган. *[Чәчәк] бездә ничек үсәр: бездә җир шлаклы, сулар мазутлы.* Х.Туфан. *Шпалалардан таланып, алардан куркып сикереп, шлаклы откосларда авыз-борын канатып, кулларны каймыктырып йөргән көннәремне исемә төшердем.* М.Мәһдиев. *--- республиканың авыл районы үзәкләренең берсендә --- хуҗалык товарлары кибете һәм шлаклы блоклар җитештерү цехы урнашкан.* Кызыл таң

**ШЛАКОБЕТОН** *и. рус* Шлак, цемент, ком катнашмасыннан ясалган җиңел бетон. *Әтием ул вакытта шофёр булып эшли иде, котельныйдан шлак алып кайта тора, без шуны цемент белән бутап, шлакобетон ясыйбыз.* Шәһри Казан

**ШЛАКОБЛОК** *и. рус* Шлак белән цемент кушылмасыннан ясалган төзү материалы. *Әллә нинди биналар юк – су куу башнясы һәм шлакоблоктан салынган ике катлы станция өе.* И.Салахов. *Бу предприятие кайчандыр төзелеш өчен шлакоблоклар җитештерсә, бүген инде аның шәһәрдә берничә кибете, тимер цехы бар.* Кызыл таң

**ШЛАМ** *и. нем. махс.* 1) Кайбер металларны электролизлаганда төпкә утырган порошоксыман продукт

2) Пар казанының төбенә утырган эреми торган минераль тоз катламы, юшкын. *Казанны шламнан чистарту*

3) Нефть һ.б.ш. сыекчаларны тондыру яки фильтрлау вакытында калган яисә буровойда забой турбинасына утырган утырма, юшкын. *Сыекча забойдагы турбинаны әйләндерә, сыекча борау ваклаган порода кисәкләрен, шламны юып алып чыга.* И.Гази. *Без елына фәлән тонна нефть чыгардык дип кенә әйтәбез. Ә һәр ел саен чыгарылган нефтьтән 300 мең тонна шлам, 50 мең кубометрдан артык нефть*

*катнашкан сулы эмульсия һәм башкалар калуын әйтмибез.* Ф.Яруллин. *Бораулаганда куерган су җир астыннан чыккан балчыкны гел үзе белән әйләндереп йөртә, шлам утырмый.* К.Кәримов

**ШЛАНГ** *и. нем.* Сыеклык, газ кебекләрне бирү, чыгару һ.б.ш. өчен резин яки брезент көпшә; эчәк. *Һавада бер самолёттан икенче самолётка, резин шланглар белән бер-берсенә һавада тоташтырып, сыек ягулыкны пешкәкләр (насослар) ярдәмендә күчерүне иң беренче булып Әмәтхан башкара.* З.Зәйнуллин. *Ася кирәкле әсбапларын алып килде, яралының аягына шприц энәсе кадады, аны озын шлангка тоташтырды.* Х.Камалов

**ШЛА́ФЫР** *и. нем. сөйл.* Бөрелгән, бөреп тегелгән урын, бөрмә. *Аклы ситса күлмәгемнең җилферди шлафыры.* Җыр

**ШЛА́ФЫРЛАУ** *ф. сөйл.* Шлафыр тегү, шлафыр белән бизәү, бөрмәләү. *Шлафырлап теккән күлмәк*

**ШЛА́ФЫРЛЫ** *с. сөйл.* Шлафыр тегелгән, шлафыры булган, бөрмәле. *Бала итәкле, шлафырлы күлмәкләргә бер дә хөрмәт булмады.* Г.Ахунов

**ШЛЕЙФ** *и. нем.* **1.** 1) Хатын-кыз күлмәгенең арттан сөйрәлеп йөри торган озын итәге. – *Әнекәй генәм! Күлмәге нинди матур! – дип сокланып пышылдады Ольга. – Сөйрәлеп килә торган шлейфы – озын итәк очы да юк.* Р.Мирхәйдәров. *Мин --- аларны [кызларны] бер-бер графиня дип тоеп, шулай эндәшәм: – Рөхсәт итегез сезнең шлейфны (күлмәк итәген дип тә аңлатам) күтәреп барырга, мәрхәмәтле дамалар?! – дим.* Р.Гыйззәтуллина-Хәмидуллина

2) *а.х.* Эшкәртелгән җирне тигезләү өчен кулланыла торган тагылмалы яки асылмалы җайланма

3) *күч.* Берәр нәрсә артыннан җәелгән, таралган әйбер. *Катер артыннан күбек шлейфы калды. Хушбуй шлейфы*

**2.** *с. мәгъ.* 1) Сөйрәлеп йөри торган озын итәкле итеп тегелгән. *Коллар да юк, Шлейф итәкне дә Анда хәзер тотып йөртмиләр.* Н.Баян

2) Нинди дә булса нәрсә артыннан таралган, җәелгән. *Шуларга карыйм да гел уналты яшемдәге саф һавалы, тилгәнле, бәрәңге басуындагы затлы исле, шлейф төтенле, кояшлы иртәне искә алам, сагынам.* М.Мәһдиев

**ШЛЕ́ЙФЛАУ** *ф. а.х.* Шлейф белән җир өстен тигезләү. *Җирне көздән шлейфлап калдыру*

**ШЛЕ́ЙФЛЫ** *с.* Шлейф (*1 мәгъ.*) белән тегелгән, сөйрәлә торган итәкле итеп тегелгән. *Атка атланып, ун метрлы шлейфлы күлмәген кигән Бузованы күрүгә, зал көчле алкышларга күмелгән.* Шәһри Казан

**ШЛЕМ** *и. рус* 1) *иск.* Өске өлеше очлаеп килгән металл хәрби баш киеме; очлым. *Каршыларына шәһәрнең эченнән ун атлы, өсләренә көбәкүз, башларына тимер шлем кигән, --- яннарына кәкре кылыч аскан гаскәр каршы алырга чаптылар.* Г.Гобәйдуллин. *Бер картинада башларына шлемнар, тимер челтәр күлмәк-көбә кигән, кулларына кылыч, сөңге, җәя тоткан борынгы сугышчылар сурәтләнгән.* Р.Кәрами

2) *тар.* Кызылармеецларның кызыл йолдызы, колакчыны һәм муенны каплый торган өлеше булган хәрби баш киеме; будёновка. *Салкынрак көннәрдә шинельдән, көннәр җылыта башлагач – гимнастёркадан, билен каеш белән буган, башына йолдызлы шлем кигән килеш йөрде.* Г.Әпсәләмов. *Кунакларның берсе түбәсе очлайган, маңгаенда зур кызыл йолдызлы шлем кигән иде.* М.Мәһдиев

3) Гаскәриләр, төзүчеләр, высотниклар, янгын сүндерүчеләр, металлурглар, спортчылар һ.б. кия торган, башны пулялардан, ярчыклардан, бәрелүсугылулардан саклау өчен металлдан, пластмасстан эшләнгән махсус баш киеме. *Комбайнёрлар таралыштылар, тракторлар инде гөрелдәп утыра иде, шлемнар киелде, күзлек киюнең кирәге юк иде ---.* М.Мәһдиев. *Шулай сөйләнә-сөйләнә, Равилә түти Ибрайга мотоциклчылар кия торган шлем сузды: «Ал, балам, ал. Кыенсынма».* Ф.Яруллин

4) Башны тышкы тәэсирдән саклау өчен һәм җитәрлек күләмдә кислород, һава басымы һ.б. белән тәэмин итәрлек итеп эшләнгән махсус баш киеме. *Космонавтлар шлемы. Водолазлар шлемы*

**ШЛЕМОФОН** *и. рус-гр. махс.* Сөйләшү җайланмалары булган, очучы, космонавт, танкистлар кия торган шлем. *Туктады танк. Башнясы ачылды, түгәрәк дисклы автомат күренде, аннан соң кысык күзле, шлемофон кигән бер баш.* З.Зәйнуллин. *Шул вакытта ук сигналны тыючы икенче ракета күтәрелде. Очучыларның шлемофонында командирның дулкынланган тавышы ишетелде: – Отставить!* З.Әхмәтҗанов

**ШЛЕЯ** *и. рус к.* **эшлия**. *Менә, пример, мин үзем шул чакларны искә төшерсәм, кыңгырау чыңлауларын, шлейләрдәге көмеш чуклар челтерәвен, гармун тавышларын ишеткәндәй булам.* Ф.Яруллин

**ШЛИФОВА́ЛЬЩИК** *и. рус махс.* Шлифовкалау эше остасы. *[Алиш:] Төрле лагерьларда сөргендар булып йөри торгач, ахырда Чехословакиягә җибәрелдем, андагы заводларның берсендә шлифовальщик булып эшләдем.* Ш.Маннур

**ШЛИФО́ВКА** *и. рус махс.* 1) Металл, пыяла, агач һ.б. өслекләрне шомарту, ялтырату һ.б. өчен абразив материаллар белән эшкәртү эше. *Нindидер берничә детальне шул кызның станогында шомарттырып алырга кирәк иде Фәриткә ул көнне, ә кызый риза булмады: «Детальләрнең шлифовка белән алдырасы җире артык калын, башта фреза белән юнып китерегез», – дип карышты.* З.Мифтахов

2) Нинди дә булса тигезсезлекләрне ышкып тигезләү, шома, ялтыравыклы итү эше. *Ул – тешләргә сак кына шлифовка ясап, фтор кушылмаларының барлык үзлекләрен үзенә җыйган флюкоал геле белән каплаудан гыйбарәт.* Туганайлар

**ШЛИФО́ВКАЛАУ** *ф. махс.* 1) Шлифовка ясау. *Детальне станокта шлифовкалау*

2) Ышкып шомарту. *Әлеге процессны туктату өчен, иң элек авыртуны басучы укол ясап, тешнең эмален шлифовкалыйбыз һәм өстеннән эмаль белән каплыйбыз.* Туганайлар

**ШЛИХ** *и. нем. махс.* Ком яки йомшак тау токымнарын юдырганнан соң калган авыр минерал кисәкчекләреннән торган утырма

**ШЛЮЗ** *и. голл.* 1) Суның биеклеге төрле булган сулыкларның берсеннән икенчесенә судноларны үткәрү өчен аерым камералары булган канал рәвешендәге гидротехник корылма. *Энҗе апа белән Свирь елгасына килгән чакларын, --- Беломор-Балтыйк каналы буйлап, гаҗәеп шлюзларга соклана-соклана, Сортавалага кадәр пароходта баруларын исенә төшерде.* Г.Әпсәләмов. *Плотина төзү тәмам булгач, пароходлар, кәрваннар, шушы шлюз аша үтеп, Тирән елганың моңарчы олы юллардан еракта торган районнарына барып җитәчәк.* С.Сабиров

2) Плотинадагы суны җибәрү өчен ябылмалы тишек. *Хәзер менә шул плотинаның шлюзлары ачылды, күрәсең.* А.Хәсәнов

**ШЛЮП** *и. голл.* 1) XVIII–XIX гасырларда туры җилкәнле, өч мачталы корабль. *Иң алда Беринг үзе утырган өч мачталы хәрби шлюп «Изге Пётр» Охот диңгезен яра.* И.Хуҗин

2) Ике җилкәнле, бер мачталы диңгез судносы

**ШЛЮПБА́ЛКА** *и. голл. диңгез.* Судноларда шлюпкаларны суга төшерү һәм бортка күтәрү өчен чыгырлы корыч җайланма. *Алгы шлюпбалканың арканы блокка кысылган. Шлюпканы суга төшереп булмаячак.* М.Юныс

**ШЛЮ́ПКА** *и. голл.* Киң, нык корпуслы, палубасыз зур булмаган судно; көймә. *Этешеп-төртешеп, мең бәла белән, ярдан шактый эчтә торган пароходка шлюпкаларда юнәлделәр ---.* А.Расих. *Берничә ишкәкче матрос белән мине шлюпкага төшерделәр.* Л.Бадыйкшан. *Шуннан соң кораблардан эре-эре шлюпкалар --- төшерелде, аларга мушкетлар тоткан диңгез пехотачылары төялде.* И.Хуҗин

**ШЛЯ́ГЕР** *и. нем.* Популяр эстрада җыры, көе. *Әле бары консерваториядә генә укыса да, Ибраһимов менә дигән затлы җырчы булачагын шәп күрсәтте – арияләр, шлягерлар бүләк итте.* Р.Харис. *Грампластинкалар дигәч тә, җыен шырды-бырды, бер көнлек шлягерлар, такмак-такмазалар җыймады ул.* Ә.Рәшит

**ШЛЯ́МБУР** *и. нем. тех.* Таш яки бетон стенага зур булмаган тишек ясау өчен кулланыла торган бер башы тешле корыч труба

**ШЛЯ́ХТА** *и. пол. тар.* Польша, Литва һәм башка кайбер илләрдә өстенлекле хокукка ия дворян катлавы. *--- поляклар теләсә кайсы этнос вәкиленә, акылына һәм кыюлыгына карап, шляхта титулы бирә, бу дәүләтне ныгытырга ярдәм итә.* Д.Заһидуллина // *сөйл.* Гомумән поляк; ләх. *Сугыш кануннары гел бертөрле: Кемдер җиңә, кемдер җиңелә. Шляхтасы китсә, Литва килгән, Ансын куган урыс кенәзе.* Н.Әхмәдиев

**ШЛЯ́ХТИЧ** *и. тар. пол.* XX гасыр башына кадәр Польшада вак дворян. *Шундук әйтеп тә куйдым: – Шляхтичларны адаштырган Сусанин дигән герой шушы Кострома ягыннан бит әле, әйеме?* Ф.Баттал. *Әмма Сенкевичның биографлары аның әтисе ягыннан татар булуын һәрдаим ассызыклыйлар, әсәрләрендә дә татар тамырлы шляхтич икәнлеге сиземләнә.* Д.Заһидуллина

**ШМОН** *и. рус жарг.* Тентү. *Коридорда нииндидер хәрәкәт башланды, камера ишекләре ачылды, кемнәрдер кычкырышты, сүгенде. – Шмон башланды, әзерләнегез. Шмонның нәрсә икәнен аңламаса да, Алмаз сорашмады.* И.Сираҗи

**ШМУЦТИ́ТУЛ** *и. нем. махс.* Китапта титул бите белән тышлык арасындагы яки аерым бүлек алдыннан аның исеме язылган, эчтәлегенә бәйле рәсем төшерелгән бит. *Беренчеләре – китапның тышлыгын, титул битләрен, шмуцтитулларны эшләү белән шөгыльләнә ---.* Фәнни Татарстан

**ШНАПС** *и. нем.* Немецлардагы спиртлы исерткеч эчемлек; аракы. *Солдатлары шундый наян, кайтып керәләр дә шнапс чөмерәләр, авыз гармунында уйныйлар, кызлар чырылдаталар.* А.Гыйләҗев. *Каһирәдән Алманиягә бер комиссия килеп җитте. Аны каршылаган милләттәшләребез мәҗлес җыйган һәм кунак табынына дәрәҗәле урынга утлы эчемлек – шнапс та тезеп куйган.* Т.Әйди

**ШНЕК** *и. нем. а.х.* Бөртекле, сибелүчән, вак кисәкле әйберләрне төяү, күчерү һ.б. өчен кулланыла торган махсус җайланма. *Борчак шулхәтле уңган, комбайннар басуның яртысына җитеп өлгерми, сигнал бирә башлыйлар. Шнектан тупырдап коелып кына тора кузовка.* Д.Бүләков. *Комбайн эшләп торганда, шнек һәм йөзмә транспортёр чабылган сабакларны берөзлексез өскә – кабул итү камерасында урнашкан алу битерына биреп тора ---.* Урып җыю машиналары

**ШНИ́ЦЕЛЬ** *и. нем. кулин.* Гадәттә, телемләп киселгән дуңгыз итен тукмаклап яки тапап йомшартып пешерелгән түгәрәк котлет формасындагы ашамлык. *Табындагы шешәләр, бокалларга салынган соклар, аш, салат, котлет, шницель, балык уылдыклары, чәнечке-калаклар, борыч-тозлар – бөтенесе, шалтыршолтыр килеп, өстәл янында утыручыларның алларына коелды ---.* Ф.Садриев. *Европалыларга үзләре гадәтләнгән шницель, яфраклы салат, паста, пицца, ә Азия халыкларына диңгез продуктлары тәкъдим ителәчәк.* Шәһри Казан

**ШНУР** *и. нем.* 1) Җептән үреп эшләнгән нечкә бау. *Рәүф бер кулына сүс дилбегә, кер элә торган озын ак шнур, иенчесенә уенчык чиләк белән кадак күтәргән иде.* А.Тимергалин

2) Аяк киемен кигәч тарттырып бәйләү өчен махсус тишекләрдән үткәрелгән бәйләгеч. *Туфли шнурлары бәйләнмәгән дә икән. Юлдан читкәрәк чыгып, уалучан ташка аякларын терәде һәм --- шәлберәп килгән шнурларны бәйләде.* А.Хәлим. *Илнар никтер җиргә иелде, ботинкасының шнурын рәтләде, ахры.* Р.Габделхакова

3) *махс.* Электр тогы, элемтә, сигнализация системалары һ.б.да изоляцияләнгән тышчалы электр үткәргече. *Иң беренче эш итеп телефон шнурын өзеп ташладыгыз.* А.Гыйләҗев. *Язилә электр плитәсен озын шнур белән вагон эченнән чыгарттырды ---.* К.Кәримов

4) *махс.* Шартлату өчен очкынны шартлагыч матдәгә китерә торган бау. *Батыршин шнурны үзенә тартты. Коточкыч шартлау бөтен үзәнлекне дер селкетте.* Ш.Рәкыйпов. *Янәшәдә генә басып торган рота командиры, солдат каршына килеп, кулындагы кечкенә йомры туп кебек шартлату пакетының шнурына ут төртте дә Габделнурның артына, окопка ташлады.* Р.Кәрами

**ШНУРЛА́У** *ф.* Шнур белән бәйләү; шнур ярдәмендә беркетеп, тарттырып кую. *Журналист «Тангейзер»ның нәрсә икәнен белми иде, уңайсызланып, ашыга-ашыга ботинкаларын шнурлады.* М.Мәһдиев. *Полковник дипломатны прокуратураның тикшерү бүлеге начальнигына сузды: – Үзегездәге сейфка бикләгез, аңарчы башка берәр бүлектәге хезмәттәшегез каршында шнурлагыз, пичәтләгез, андагы кәгазьләр бик күпләрнең тормыш бәясенә тора, зур кешеләрнең...* Р.Мирхәйдәров

**Шнурлап кую** Шнурланган хәлдә калдыру, шнурланган хәлдә тоту. *Мопед рамына көрәк белән ломны әйбәтләп шнурлап куйды, кадими сөякләрне тутыру өчен багажнигына ике арыш капчыгы кыстырды.* А.Тимергалин

**ШНУРЛЫ** *с.* Шнуры булган; шнур белән бәйләнә торган, баулы. *Сылу гапгади җиңсез ак кофта кигән, беләгенә шакмак сәгать таккан ---, аякларында өсте шнурлы спорт тапочкалары иде.* М.Мәһдиев. *--- агач карават --- операция өстәле кебек, кайчылык сиртмәсенә эленгән озын шнурлы лампочка астына туры китереп уртага куелган.* К.Кәримов

**ШОБАГА** *и. монг.* 1) Берәр мәсьәләне хәл итү яки нәрсәнең дә булса кем өлешенә чыгасын белү өчен, билгеле кешеләр арасында уйнатылган, гадәттә, бер төрле предметлар арасыннан тамгаланганын тартып чыгарган яки бау (таяк) тотып, кулы өстә калган кеше

җиңүче булып саналган уен; жирәбә. *Урманны ике-өч елга бер, болыннарны һәр ел бүлешәләр. Һәркем шобагасына чыккан өлеше белән файдалана.* Г.Ибраһимов. *Минем өчен искиткеч бәхетле булды ул көн. Шобагада мин өскә чыктым.* Н.Фәттах

2) Шундый уенда отучы өчен билгеләнгән тамгалы предмет. *Печәннең иң куе төшкән урынына килеп җиткәч, шобага алып торучы кеше: – Бикбулат абзый! – дип кычкырды.* Г.Бәширов. *Әмма Дию пәриенең юлына беркемнең дә ятасы килми икән. --- Кешеләр шобага тотарга булалар. Шобага Азәм дигән бер егеткә чыга.* Г.Гыйльманов

3) *иск.* Җир бүлгән вакытта бер төркем кешегә (гадәттә 8 иманага) бирелә торган җир кишәрлеге. *Кәрим карт бер дә якын килмәде: – Нинди кайту әле ул, – ди... – Типсә тимер өзәрдәй уникe җегет килеп, бер шобага печәнне дә бетермәгәч, ул нигә ярый...* Г.Ибраһимов. *Явым-төшем күп булганлыктан, шобагасына биш пот урынына бер генә пот чәчелгән җирләребездә иген котырып уңды.* Л.Гыймадиева

4) *куч.* Дини карашлар буенча, Алла тарафыннан һәр кешегә алдан билгеләнеп куелган күрәчәк, язмыш, тәкъдир. *Хәдичә дә, бәхетенә чыккан шобагасына разый булган кеби, бераз сабыр итте. Ләкин сүзе бетте, көләч йөзе ябылды, кашлары төште... Туй җитте.* Г.Исхакый. *Следователь Бикчәнтәев алдында үрә катып торганда, бу шомлы шобага миңа гына төшкәндер, нинди-дер бер аңлашылмаучылык белән бары тик мине генә «или» торгандыр, дип пошына идем.* И.Салахов // Үзенә тигән өлеш, бәхет. *Элек байлар рәхәт чиккән, Хәзер безнең шобага.* Г.Камал. *– Габдулла шәкерт, әйткән нәзерем барие, кем дә кем Сылукайны арыкландыра, шул киявем булыр дигән идем. Ул шобага сиңа насыйп булган икән.* А.Гадел

◊ **Шобага салу** Нәрсәнең дә булса кем өлешенә чыгасын белү өчен шобага (*1 мәгъ.*) уйнау. *Кызлар бу егеткә үзләренең һөнәрләрен өйрәтмәкче булалар. --- Шобага салгач, иң элек өйрәтергә олы кыз чыга.* Әкият. *Башка чара юк, балык корбан сорый. Шобага салырга шулай да мәҗбүр булалар.* Г.Ибраһимов. **Шобага тарту** *к.* **шобага салу**. *Беренче көнне, шобага тартканны карарга дип, Хәлим дә барды.* И.Гази. *Сугыш алдыннан корәеш халкы, яуга барыргамы-юкмы икәнен белү өчен, үз гадәтләренчә фал ача һәм шобага тарта торган иде.* Ф.Яхин. **Шобага тоту** *к.* **шобага салу**. *Мин утынлыктан озын гына чыбык алып килдем. Шуннан соң без көлешә-көлешә шобага тота башладык.* Н.Фәттах. *– Әйдәгез, кызлар, шобага тотышыйк, – диде Әсма. Кызлар, --- орчыкны тотып, кулларын күчерә башладылар.* Х.Сафина

**ШОВИНИЗМ** *и. фр.* Башка милләтләрне эзәрлекләү, изү һәм кимсетү, милләтара дошманлыкны һәм үз милләтеңнең өстенлеген пропагандалаудан гыйбарәт милләтчелек идеологиясе. *Шәһәр янындагы авылларда татарларны көчләп чукындыру башлана. Чын мәгънәсендә тәре походы. Биредә шулай рус шовинизмы тантана итә.* Х.Камалов. *Ә сезнең кыланмышлардан интерфронт һәм бөек державачыл шовинизм исе килә.* З.Зәйнуллин

**ШОВИНИСТ** *и. фр.* Шовинизм тарафдары. *Мин ул шовинист генерал белән сөйләшергә теләмим!* З.Зәйнуллин. *Руцкой чиктән ашкан үтә явыз шовинист булуы белән бергә татар халкының куркынычлы кан дошманы да икән.* Н.Нәҗми

**ШОВИНИ́СТИК** *с.* Шовинизмга мөнәсәбәтле, шовинизм белән сугарылган. *Кайбер шовинистик сәясәтчеләр, үз башына ашкынган козгын кебек, Татарстанның республика булып яшәренә күп калмады инде, дип тә каркылдыйлар.* Р.Фәйзуллин. *Россиянең, СССР башлыкларының шовинистик позициягә басып, руслардан башка халыкларга кимсетеп карау политикасына бик туры килә иде бу караш.* А.Хәсәнов

**ШОВИНИ́СТКА** *и. рус* Шовинист хатын-кыз. *[Габдулла:] Рокыя туташның ул кадәр шовинистка икәнен мин белмәдем.* Ф.Әмирхан. *«Бездә ике дәүләт теле», – диюем өчен, чираттагы урыслар да «шовинистка» дип бакырырга кереште.* Безнең гәҗит

**ШОВИНИСТЛЫК** *и.* Шовинист карашлары, шовинист позициясе. *Ул үзе Кырым татарларының туган җирләренә кайтып урнашуына һич тә каршы түгел, --- әмма үз автономияләрен Украина карамагында төзүләрен тели. Василий – украин егете. Шуңа күрә мин аның бу шовинистлыгын аңларга тырыша идем.* З.Зәйнуллин. *Кытайда туып үскән, кытайларның шовинистлыгына чыдый алмыйча, Измиргә күчеп яшәргә мәҗбүр булган ир уртасы Мөслих бәй ни өчен җылый?* Р.Батулла

**ШОК** *и. фр. мед.* Баш мие зарарлану, күп кан югалту, көчле психик тетрәнү һ.б.ш. нәтиҗәсендә организмдагы тормыш процессларының нерв системасы тарафыннан идарә ителүе кисәк бозылу хәле. *[Әнвәр яралы аягын] --- ялгыш кына кыймылдатып куйса да, авыртудан аңын җуя, нииндидер шок була иде шикелле.* Х.Камалов. *Сәфәргалине, кыз күз алдында аңын югалтканчы кыйнап, арбага салдылар һәм алып кайтып киттеләр. Шок хәлендә калган кыз, елый-елый, станциягә таба йөгерде ---.* Айгизә

**ШО́КЕР** *и. ингл.* Кешене яки хайванны югары көчәнешле электр тогы белән вакытлыча хәрәкәтсезләндерергә сәләтле, гадәттә үзеңне саклау чарасы буларак кулланыла торган компакт җайланма; электрошокер. *Диләрә үзе белән шокер йөртә*

**ШОКОЛАД** *и. исп.* **1.** 1) Какао белән шикәргә төрле тәмләткечләр кушып ясалган порошок яки куе масса

2) Шундый порошоктан конфет яки плитка формасында эшләнгән татлы ашамлык. *Искәндәр белән Рөстәм хәзер шоколадны бүселгәнче ашыйлар ---.* А.Гыйләҗев. *Чәчкә бик бай табын әзерләде. Тәмле-тәмле җимешләр, матур шешәле соклар, төрледән-төрле шоколадлар, бананнар, апельсиннар куйды.* Ф.Яруллин

3) Шул массадан су яки сөт кушып әзерләнгән эчемлек. *Кайнар шоколадның рәхәт җылысы тәненә тарала баруын тоеп, аны эчеп бетергәндә генә, күршесе, газетын бер якка куеп, илтифатлы елмайды* **---**. Р.Мирхәйдәров. *Баллы әйберләр, кофе, кайнар шоколад, зефирлы куе какао, хуш исле пешкән әйбер – болар барысы да хюгге.* Сөембикә

**2.** *с. мәгъ.* Шул массадан эшләнгән, составында шул порошок булган. *Шоколад кәнфитне тешләштереп, куе кайнар чәйне әз-әзләп йоткан арада, Мортаза аның сорауларына кыска-кыска гына җавап бирде ---.* М.Маликова. *Малайлар, рәхмәт тә әйтмичә, ызгышаызгыша, пакетта булган шоколад кәнфитләрне бүлешә башлады.* З.Мәхмүди

**ШОКОЛА́Д АГАЧЫ** *и. бот.* Стеркулчалар семьялыгының теоброма ыругыннан алсу ак чәчәкле, орлыкларыннан май сыгып алына, түбеннән шоколад ясала торган тропик агач. *Тропик урманнарда шоколад агачлары үсә*

**ШОКОЛАДЛЫ** *с.* Шоколад кушып эшләнгән. *Әмма көчек шоколадлы йомшак конфетны кабып йоткан иде инде.*

Г.Сабитов. *Чәчкә исемлесе кап-кара майга баткан кулы белән кызга шоколадлы вафли китереп тоттырды.* Р.Рахман

**ШОЛГАН** *и. зоол.* Җир тычканнары семьялыгыннан вак бөҗәкләр, аларның личинкалары, яңгыр суалчаннары белән туклана торган тычкансыман кечкенә җәнлек, имезүче хайван; җир тычканы; *русчасы:* **землеройка**

**ШОМ** *и. гар.* 1) Эчтән күңелне борчып торган тынычсызлык, курку хисе. *Мин үзем --- төрле хорафатларга ышана торганнардан түгел. Әмма Мәгыйшә карчыкның бик тә үтемле гыйбарәләр белән нығытып әйткән әлеге сүзләре минем күңел түрендә кара шом булып утырды да калды.* М.Хәсәнов. *Аның йөрәген ниндидер билгесез шом, тынычсызлык били башлый.* З.Зәйнуллин

2) Куркыныч нәрсә, дәһшәт. *Кешеләр тынып калган, алар өстендә кара шом канат җилпи, һәрберсенең эченә курку төшкән һәм гипнозлаган кебек иткән.* Х.Камалов. *--- алда ике карчык, уртада Хәлим сөйрәлә. Явыз аждаһа авызына кергән кебек, алар сихер алачыгының караңгылык, салкынлык, шом аңкытып торган ишегенә шуышып кереп киттеләр.* Г.Гыйльманов

3) *күч.* Начар, яман нәрсә. *Бу дөнья гыйльме дип Әбелхарис масайгандыр... Тәкәбберлек дигән шомга Галим зат мөбтәлә булса. Гаҗәпме бу?* Н.Исәнбәт

◊ **Шомга төшү** Шикләнү, тәшвишләнү, курку. *Мин кинәт сискәнеп куйдым, капитан, теге вакыйганы тагын искә алып, бөтен команда алдында тиргәп ташламагае дип шомга төштем.* С.Сабиров. *Шәрифә аның балалар белән ничек таләпчән, нык сөйләшкәнен, үзен ничек эре тотканын җентекләп күзәтте. Һәм шомга төште: --- бу кыз аңа --- башкалардан өстен булырга күнеккәндер кебек күренде.* М.Маликова. **Шом салу** Курку хисе барлыкка китерү, шик тудыру. *Бу хәбәр карчык-коры арасында козгын кебек шом салып йөрде.* М.Мәһдиев. *Бу көлү барчасының да күңеленә шом салды.* Х.Ибраһим. **Шом төшү** Курку хисе барлыкка килү, шик туу. *Кайдадыр --- кан дәрья булып ага. --- Монда тик аның куәтле шаулавы гына килә, шуңардан йөрәккә бераз шом төшә.* Г.Ибраһимов. *Бу хәбәрләрдән авыл кырмыска оясы кебек мыжгыды, кешеләрнең эченә шом төште.* Ф.Бәйрәмова

**ШОМА** *с.* **1.** 1) Тип-тигез, кытыршы, чыгынкы яки батынкы урыннары булмаган. *Әбүзәр абзый китап шкафлары янына барды, ---тамырлары беленеп торган кулы белән шома такта695ларны сыйпады* ---. Г.Әпсәләмов. *Кул графинга җитте, ләкин бармаклар шома пыяланы эләктерә алмадылар: графинның муены буенча шуыштылар гына.* Ф.Яруллин // Дулкынсыз, шадрасыз. *Су өсте шома, анда аллы-кызыллы шәфәкъ чагылган, --- монда су кап-кара һәм бик тирән сыман.* Г.Әпсәләмов. *Күтәрмәләрем шома бозда таеп, нәкъ күлдәвек уртасына егылдым.* Г.Сабитов

2) Тузгып, таралып тормаган, тигез итеп таралган. *Көзгегә карап, шома чәчен сыпырып, толымын беретына тутырып киде дә --- улын кулына алды.* М.Маликова // Бөдрәләнмәгән, көдрә булмаган. *Тик бу юлы аннан тамчы да шикләнмичә, тәрәзәмне ачтым, кулымны сузып, бозау кадәрле этнең елтырап торган чиста, шома йонын сыйпаштырырга тотындым.* Сөембикә

3) *сөйл.* Тулы, симез, таза. *Люда хуш исле күбек белән малайның авызборынын күмеп, --- кулына бритва алды да, тегенең шома, шәп яңагыннан (ә Кремльдә эшләгән кешенең яңагы шәп, шома гына була) бер сыпырды, ике.* М.Мәһдиев. *Ломако да килгән елындагы ябык, ертык эрзинкә итекле --- йолкышны танырлык түгел. Яхшы гына симергән шома гәүдә, бик шәп костюм-чалбар, каракүл якалы җылы пальто ---.* З.Зәйнуллин

4) Ыспай, купшы, матур. *Ул карарга да таза күренә, өсте-башы да иптәшенекеннән шомарак иде.* Ш.Камал

5) *күч.* Телгә, сүзгә бай, сөйләргә яки язарга оста (кеше тур.). *Авылда без төшкән фатирның хуҗасы – әле карт лыкка бирешмәгән, төп кебек нык, үткен күзле, шома сүзле сиксән яшьләрдәге мөлаем карт.* Ш.Галиев. *Бар ул шундый мөдирләр – Телгә бик шома алар, Коры мунчала белән Аркаңны юа алар.* З.Мансур // Бәйле, төзек, матур төзелгән, тышкы эффектка ия (сөйләм тур.). *Мин аны анда мөхәррир Хамматовның балдызы булган өчен генә басылган дип тә әйтмәс идем. Аның теле шома, ул андый хикәяләрне «маташтыра» ала.* Г.Әпсәләмов. *Зәй райкомга мөрәҗәгать итте. Анда да коры вәгъдә. Барысы да шома сүзләр белән алдау булды.* Х.Камалов

6) *күч.* Яхшы, шәп, оста; җитез, җиңел, төгәл. *Низами, җитез, шома хәрәкәтләр белән бөгелә-сыгыла, безне таныштыра башлады.* М.Әмир. *Каһир җирнең басынкы сулышын, шома хәрәкәтен сизеп, тоеп утырды ---.* Ә.Гаффар

7) *күч.* Каршылыклар, кыенлыклар булмаган, җиңел. *Шома тормыш юлында гизгәнеңдә яңлышып тайсаң... Белеп тор: мин чыгармын таш күңелләләр арасыннан.* Г.Тукай. *Шома үсеш*

8) *күч.* Эшкә оста; үткен, елгыр, хәйләкәр. *Була шома кешеләр! Тормышта үз фәлсәфәсен билгеләп алган да бүтәннәр исәбенә яши бирә.* Ш.Галиев. *Чүпрәк-чапракка оста төрелгән шома кызлар саф күңелле егетләрне мәкер җәтмәләренә каптыралар да инде.* А.Гыйләҗев

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Тигез итеп. *Багана бик шома ышкылаганга, күрәсең, ул елны әтәчкә бер егет тә менеп җитә алмады.* Татарстан яшьләре

2) Тигез итеп, яткырып, күпертмичә. *Ул чакта Сәйфуллинның төсе бөтенләй башка иде. Житү чәч шома таралып артка җибәрелгән була.* Г.Ибраһимов

3) Ыспай, купшы итеп. *Асрау ишек ачкач та, кереп әйтергә өлгермәде, утыз биш-кырык яшьләр чамасында, шома гына киенгән, таза бер кеше тәкәллефсез генә туп-туры безнең янга килеп керде.* Ш.Камал. *Маһирәттәй --- Әбрар абый белән шәһәрчә килешле, шома киенгән килене, ялбыр кара чәчле оныгы Валериклар арасына кереп кунаклаган ---.* М.Рәфыйков

4) Төртелмичә, йөгерек; матур итеп, оста итеп. *Әгәр синең әсәреңдә укучы өчен яңа шигъри фикер юк икән, ничек кенә шома язсаң да, ул чын мәгънәсендә әйбәт әсәр була алмый ---.* В.Нуруллин. *Татарча шома гына сукалыйсыз икән, Эдуард әфәнде.* Н.Гыйматдинова. *Тырыша-тырмаша торгач, башта «Тамчы гөл»не, аннан Тукайның «Туган тел» көен шома гына уйный башлады Гали.* Г.Галиев

5) *күч.* Бернинди каршылыклар, кыенлыклар күрмичә, авырлыксыз, ансат кына, җиңел генә. *Чит тел белән дә эшләр бик шома гына бармады.* К.Тимбикова. *Хәер, бар эш тә шома гына бара дип әйтү дә дөрес булмас, аратирә команда тормышында киртәгә сыймаган күңелсез хәлләр дә булгалый.* С.Сабиров. *Имтиханнарны шома гына тапшырып булмады, тагын бер айга калырга туры килде.* М.Маликова

6) *күч.* Башкаларның каршылыгына, ризасызлыгына очрамыйча; тавыш-гаугасыз, талашмыйча, кычкырышмыйча. *Син нәрсә, шома гына эштән китеп*

*котылырга теләмисеңме?* Т.Миңнуллин. *Бер авыл кызын алганда да, шәхси тормышы шомарак барыр иде.* А.Тимергалин. *Шуңа күрә җыелышның отчёт өлеше шома гына барды дияргә була.* В.Нуруллин

7) *күч.* Бик оста, кимчелексез яки хәйләне сиздерми генә. *Миргали, язучы әйткәнчә, бу эшләрнең барысын да бик оста, астыртын һәм шома эшли.* М.Җәлил. *Менә шәп тә булыр иде әгәр карчыкны шул Яңа Бистә тарафларына озатып булса! Ләкин моны бик оста, шома эшли белергә кирәк.* Ә.Еники

8) *күч.* Җитез, җиңел итеп. *Хәтимә апа, боз өстеннән шуып килгәндәй шома гына басып, егет каршына чыкты.* Л.Ихсанова. *Мамак шул танкка каршы граната белән сугышчы җибәрергә кирәк дип тапты. Ләкин кемне? Үткен зиһенле, еландай шома хәрәкәтләнүче булсын.* Х.Камалов

9) *күч.* Үткен, үтемле, тәэсирле итеп. *Кулак тибы шома эшләнгән.* М.Җәлил

**3.** *и. мәгъ.* Эшкә оста, үткен, хәйләкәр кеше. *«Алыйк микән, алмыйк микән?» дип ялындырып кына йөргән кайбер шомалар соңга таба --- бер атлам җир, бер төшкән яфрак өчен көрешеләре --- белән дошманлашып беттеләр.* А.Гыйләҗев. *Әдәбиятта мөгезсезләр, мүкләкләр, шомалар күбәю кем өчендер файдалы иде.* М.Вәлиев

◊ **Шома каләмле** Оста әдип, шагыйрь, язучы һ.б.ш. *Ул --- фольклорчы, шома каләмле журналист, үз иҗатташларына һәрчак хаерхаһлы булган ярдәмчел дус һәм --- милләт язмышын үз язмышы иткән фидакяр шәхес тә.* Р.Вәлиев. **Шома тактадан (таудан) шудыру** 1) Майлап-җайлап игә китерү, күндерү, ризалату; 2) Алдау, юмалап алдау. *Сизәм: шома тактадан шудыралар монда.* Ватаным Татарстан

**ШОМАКАЙ** *с.* **1.** 1) Эшкә оста; шома, үткен, елгыр. *Кирәк икән, ул йомакай да, шомакай да; кирәк икән, караелан булып куеныңа керә, дәрвиш яки галим, шымчы яки вәзир дә ул Биккол сәүдәгәр.* М.Хәбибуллин. *Уйгын үзе Афанасий Калистратов атлы сәүдәгәрнең капкасын какты. Шомакай дигән даны таралган иде Калистратовның. Йөзе шома, гәүдәсе шома, сүзе шома.* М.Әмирханов

2) Эш яратмый, вакытын буш йөреп уздыра торган, җилкуар, җилбәзәк, җиңел холыклы. *Мотоциклны кызлар йөртү өчен алган шомакай егетләр Ык буеның аулак урыннарын, әрәмә араларын бик еш пычратып китәләр ---.* Г.Бәширов. *Шомакай егет, батыраеп китеп, бичаралыктан гәүдәсе тетрәнгән, тыны сикергән, тамак төбе ябышкан кызны диванга яткырмак булды.* Б.Камал

**2.** *и. мәгъ.* 1) *бот. к.* **шомакөпшә**. *Аннары шомакайдан су сиптергеч ясап уйныйлар. Тагын ярыш китә: кем сиптергече суны ераккарак җибәрә, шул – җиңүче.* Ә.Баян

2) Эш яратмый, вакытын буш йөреп уздыра торган кеше, җилкуар; җиңел холыклы кеше. *Гомер буе ныклы оя коралмыйча, матур хатыннан матур хатынга йөрүче шомакай ахырда үзенең язмышын менә ничек сурәтли.* К.Миңлебаев

3) Буш сүз сөйләргә яки язарга оста; икейөзле, ялагай. *Гаяз Исхакый теле демагоглар теле түгел. Ә бит бүгенге әдәби телне еш кына демагоглар һәм шомакай вә шамакай лыгырдыклар, тел бистәләре, төрле бушбугазлар эшкә җигәргә маһир...* А.Тимергалин

**ШОМАКАЙЛАНУ** *ф.* 1) Ыспайлану, купшы, шома, көяз төс алу, купшыланып йөрү

2) Гаепсез, гөнаһсыз тыйнак кеше булып күренергә тырышу. *Элеккеге җитәкчебез шомакайланырга ярата иде*

**Шомакайлана башлау** Шомакайланырга тотыну

**Шомакайлана тору** Гел, даими яки хәзерге моментта шомакайлану. *Председатель булган кешебез, мыегын сыпыргалап, шомакайлана торды, колхозыбыз урынтын сырхау шикелле гел сыза торды.* Г.Бәширов

**ШОМАКӨПШӘ** *и. бот.* 1) Чатырчәчәклеләр семьялыгыннан дымлы җирләрдә үсә торган эче куыш сабаклы, ак яки саргылт яшел чәчәкле, каурыйсыман яфраклы ашарга яраклы үләнчел үсемлек; курай үләне, шүре үләне, шүрелек; *русчасы:* **дягиль, дудник лекарственный**. *Шуннан елга буйларында, үзәнсу, уйсу җирләрдә какы, кузгалак, юа, урманнарда бәбәк, балтырган, шомакөпшә кебек ашарга яраклы әллә күпме ризыклар калкып чыга.* С.Поварисов. *Ач-ялангач балачак елларында әнә шулар үзләренең алабуталары, кычыткannары, юа-кузгалаклары белән, --- шомакөпшәләре, җиләк-җимешләре, куырган бодайлары-борчаклары белән аларны үлемнән коткарып калдылар.* Ф.Садриев

2) *күч.* Тыштан гына ялтырап торган, буш, надан кеше турында. *Юкса теге шомакөпшә муллалар, хәлфәләр берни дә белмиләр.* Х.Кәрим

**ШОМАЛАНУ** *ф.* 1) Сырлар, җыерчыклар бетү, тигезләнү. --- *кышкы салкын, суык җилле буран уйнап моржаларда ыжгырып-сызгырып үзенең ачулы көене улаганда да, маташа торгач, кояш җиңеп китеп, шул китмәскә яткан калын карларны, суның шалтырап, шомаланып агуына көнләп, аны тотып торган бозларны эреткәндә дә язам.* Г.Исхакый. *Шадралары шомаланып югалган, күзләре шешенке кабаклары арасыннан күренмәс булган Вафа генералны күргән ефрейтор сыман турайды.* А.Гыйләҗев

2) *к.* **шомакайлану**

3) Берәр эштә шомару, остару, берәр эшне оста башкарырга өйрәнеп китү

**Шомалана бару** Торган саен ныграк шомалану. *Хәзер мошенниклар шомалана бара*

**Шомалана төшү** Бераз шомалану; тагын да шомалану

**Шомаланып бетү** Тәмам, бик нык шомалану. *Гармун уйнап шомаланып бетү*

**ШОМАЛАТУ** *ф.* 1) *к.* **шомарту**

2) Кимчелекләрне яшереп, тышкы ялтыравыгын гына күрсәтү. *Монда экспонатларны шомалатып тезгәннәр төсле күренә.* Г.Гали

**ШОМАЛЫК** *и.* Шома булу сыйфаты. *Каршыдагы егет аңа үзенең шомалыгы һәм елтыр күзләре белән нигәдер бурсык сыман тоелды.* М.Мәһдиев. *--- яшь чагында читтә йөреп шомарып беткән һәм шул шомалыгы, үткенлеге, тәвәккәллеге аркасында «әйтсә эшли» кушаматы алган Галим абзый мине тыңлап тормады.* В.Нуруллин. *Кайбер мәкаль-әйтемнәргә кыскалык, шомалык, аһәңлелек җитми ---.* Р.Юсупов

**ШОМАРТУ** I *ф.* 1) Нәрсәнең дә булса өслеген юнып, ышкып һ.б. юллар белән шома итү, шома хәлгә китерү. *Кызыл граниттан шомартып ясалган кабернең баш очына бюст куелган.* З.Зәйнуллин. *Ул хәзинә бер чоландагы шомартып ялтыратылган такта, фанер, борыс кисәкләре, җилем, лак, буяулар иде.* М.Маликова. *Ятьмә таягын нык агачтан ясыйлар. Аны яхшылап шомарталар.* Яшь натуралистларга

2) Җыерчыкларын, сырларын, шадраларын бетерү, тигезләү, шома, тигез итү. *Карчык беркөнне, картның маңгай сырларын шомартырга телгәндәй, үзенең шундый ук буразналы куллары*

*белән сыйпый-сыйпый, авыр сулыш алган: – И картым, син дә бирештең ләбаса.* Г.Әпсәләмов. *Ике бияләйнең берсен гарип кулына киде, аны сыйпап шомартты ---.* З.Зәйнуллин

3) Йөри-йөри тигез хәлгә китерү, такырайту. *Ерак та түгел юл тигезләгеч машина гаять зур тимер кәтүге белән, немецлар тараткан дегетле вак ташны таптатып, юлны шомартып йөри.* Ф.Яруллин. *Будённый районы эчендә йөргән машина һәм арба тәгәрмәчләре күпергә төшә торган юлны шомартып, тәмам беләүгә әйләндереп бетерә торганнар иде.* К.Миңлебаев

4) Тузгытмау, шома итеп кую. *Сары чәчләрен шомартып артка тараганга, маңгаендагы ике нечкә сыры аермачык күренә, уң як ирен читендәге түгәрәк миңе ак йөзенә сабыйларча экерсезлек төсмере бирә.* М.Маликова

5) *күч.* Чая, үткен кешегә әйләндерү; аң-карашын үстерү, аңлы, тәҗрибәле итү. *Практика аны тиз шомартты.* Ш.Камал. *Комсомол эше кешене шомарта, хәйләгә, алдауга, мәкергә, кыскасы, сыртка әйләнеп төшмәскә өйрәтә.* Т.Галиуллин

6) *күч.* Тел, сөйләм, язуда яки әсәрдә булган кытыршы, җитешмәгән якларны, кимчелекләрне төзәтү. *Төннәр буе утырып, шактый шигырь язган. Шомартасы, эшкәртәсе кирәк булганга, ул аларны папирос кәгазенә күчереп тормаган.* Р.Мостафин. *--- төрекчәмне шактый шомарттым.* Р.Батулла

7) *күч.* Кимчелекле якларны яшерү яки тышкы яктан гына булса да бетерергә тырышу, тәртипкә китерү. *Кооперативларда эшләүчеләр үзләренең чуалган эшләрен шомартырга, очны очка туры китерергә ашыктылар.* К.Нәҗми

8) *күч.* Кискен куелган, житди булган яки кемгә дә булса кыенлык китерергә тиешле эш-мәсьәләне өстән-өстән генә эшләү, читләтеп үтү; йомшарту. *Анныры килеп, өстән шомартып кына узарга мөмкин булганда, нигә андый төп мәсьәләләрне шундый кискен итеп куярга?* Г.Әпсәләмов. *Тормышны шомартып күрсәтүне алга сөргән торгынлык еллары туры сүзле жанрны санга сукмады.* Ш.Галиев

9) *күч.* Кемне дә булса алдау, хәйләләү. *Дәүләт аны ничаклы таларга, алдарга тырышса да алдатмады. Шомартып яши белде. Белеме булмаса да, амбар тирәсендә чуалды.* Т.Миңнуллин. *– Әй, син дә шомартасың, – дип, Тәүгиз ничектер ачу белән әйтеп куйды. Аның тавышыннан, син дә ялганлыйсың, дигән кебегрәк аңлашылды.* Х.Камалов. *Агач төймәле «санагычы» белән ул бик зур суммаларны чыгара, үзәктән киләкитә торган оста тикшерүчеләр аның ялгышын, хатасын таба алмый интегә. Каядыр очны яшергәнен, шомартканын сиземлиләр, исбат итә алмыйлар.* Т.Галиуллин // Мәзәк өчен кешене алдалау, кызык итү, көлкегә калдыру. *Кичен урамда «Шоманы [кушамат] шомарткаяннар» дип такмак әйтә башлыйлар.* Г.Әпсәләмов

10) *күч.* Матурлату, купшылату, ыспай итү. *Әһлетдин абзый да, сакалмыекны төзәттереп, кием-салымын да әзрәк шомартканга, теге вакыттагыдан күп яшь күренә иде. Башында яңа кара түбәтәй.* Г.Әпсәләмов

**Шомарта башлау** Шомартырга тотыну. *Хәер, баштарак мин үзем дә шундый идем. Ә соңыннан, Рафаэль дускай, план сине, әлеге плитә белән ташкирпечләр арасына кыстырып, шундый шомарта башлый!* Ә.Сафиуллин

**Шомарта бару** Торган саен шомарту. *Проектка кадәр бозда аяклана алмый азапланган артистлар күзгә күренеп үзләрендә көч, егәр табып, моңа кадәр яшеренеп яткан әллә никадәр резервларын эшкә җигеп, осталыкларын бозның үзе кебек шомарта баралар.* Шәһри Казан. *Сөйләгән саен, текстын камилләштерә, шомарта бара.* Бөгелмә авазы

**Шомарта тору** Әледән-әле шомарту; алдан шомарту. *Бернигә карамыйча яз, каләмеңне шомарта тор.* Ф.Яруллин. *Әле, ул кайтканчы, идәнлекләрне шомарта торса да яхшы.* Д.Булатова

**Шомарта төшү** Аз гына шомарту; тагын да шомарту. *Таҗикчагызны шомарта төшәргә кирәк, Бохарада ансыз уңышлы эш алып бару кыен.* Т.Әйди. *Җилгә каршы барып, кычкырганыңны ишетмәсәм, бауны шомарта төшәрсең бераз.* Р.Мөхәммәдиев

**Шомартып алу** Тиз генә яки бер мәртәбә шомарту. *Кәгазьне тагын бер кат шомартып алды да йотылды.* Ф.Латыйфи. *Болай иткәндә кәгазь чүбекләнми, шулай да тырнак йөзе белән «яралы урынны» ышкып, шомартып аласың.* М.Галиев

**Шомартып бетерү** Ахырга кадәр шомарту, шомартуны төгәлләү. *Сөякләрне бик оста кимереп, тәмам ялтыратып, шомартып бетергәннәр.* А.Хәсәнов. *Без, малайлар, кечкенәдән шунда уйнап үстек, аның ташларын ыштанарыбыз белән шомартып бетердек.* И.Хуҗин

**Шомартып җибәрү** Бераз шомарту. *Машинаңны буярга, бәрелгән-сугылган җирләрен шомартып җибәрергәме – шәһәрдән чыгу юлында Варданян көтеп тора.* Р.Мирхәйдәров. *Әнә шулай ерактан күренмәгән, әмма шомартып җибәргәч ялтырап киткән энҗеләр кебек 500 дән артык бала катнаша әлеге бәйгедә.* Ватаным Татарстан

**Шомартып килү** Күптәннән хәзергәчә шомарту. *Русия күләмендәге җырчыларны алсак, андагы халык артистлары да үзләренең осталыкларын гомер буе шомартып килә.* Кәеф ничек?

**Шомартып кую** Алдан шомарту; шомарткан хәлгә китерү. *Кайсыбер кешеләр поэма кебек поэманы (тәнкыйть фикерләре әйтелгәннән соң) бер төн эчендә (!) үзгәртеп, шомартып куялар.* Н.Нәҗми. *Чиркәү төзүче балта осталары араталарны юкартып, түгәрәкләп шомартып куйганнар.* Г.Рәхим

**Шомартып тору** Сөйләү вакытында шомарту белән мәшгуль булу; һәрвакыт, гел шомарту. *Энә урлап тотылмаган карак осталыгын дөя урлап тотылганга кадәр шомартып тора.* Х.Бәдигый. *Директор үзе, уку-укыту бүлеге мөдире Реваль Раков дәресләргә даими кереп, җентекле анализ ясап, укытучыларның һөнәри-иҗади осталыкларын шомартып тордылар.* Безнең гәҗит

**Шомартып чыгу** Һәрберсен берәмберәм шомарту. *Алар кырынган арада, ул кичә язган шигырьләрне тагын бер кат карап-тикшереп, кирәк булса, шомартып чыга.* Р.Мостафин. *Укытучылар белән яңадан бер тапкыр тикшереп, төзәтеп һәм кытыршырак, килеп җитмәгәнрәк урыннарын шомартып чыктык.* Г.Галиев

**ШОМАРТУ** II *ф. к.* **шомрайту**. *Өйгә таба бик теләп, бик җиңел кайткан ат, иясенең мондый кыланышына гаҗәпләнеп, колагын шомартты, башын боргалады.* Н.Фәттах. *Әтисе чыгып караса, лапас астында колакларын шомартып кара бия басып тора.* М.Мәһдиев

**Шомарта башлау** Шомартырга тотыну. *Полковник айгырның колакларын шомарта башлаганга игътибар итеп тормады.* З.Зәйнуллин

**Шомартып алу** Кыска вакыт эчендә, тиз генә шомарту

**Шомартып кую** Бер тапкыр шомарту. *Кинәт бахбай колакларын шомартып куйды*

**Шомартып тору** Озак, даими рәвештә яки сөйләү моментында шомарту

**ШОМАРУ** *ф.* 1) Ышкылу, күп юылу, майлану һ.б.ш. сәбәптән шома, тигез, ялтырап торган хәлгә килү. *Ак ватман кәгазь өстеннән узган карандашның кара графит эзе тәрәзәдән төшкән кояш нурларында беләүләнеп шомарган таштай ялтырый.* Н.Хәсәнов. *Эшли-эшли шомарган төрән калагында янә ай нурлары ялтырап китте.* Р.Низами

2) Сырлар, җыерчыклар бетү (тән тур.). *Руслан Даулатовичның маңгае шомарды: аудитория җиңел сулап куйды, димәк, Заһид бу юлга исән-сау кала икән әле.* З.Хөснияр

3) Йөри-йөри тигез хәлгә килү, такыраю. *Чана эзләре күзгә боздай шомарды, кояшта күзне чагылдырып ялтырыйлар.* М.Хуҗин. *Шактый ара узгач, Ләмига бабасының таш кебек шомарган юлдан да сөртенә-сөрлегә генә үзенә каршы килгәнлеген күрде.* Р.Рахман

4) *күч.* Кабатлау, күп күнегүләрдән соң нинди дә булса эшкә остарып китү, эшне яхшырак башкара башлау. *--- тәҗрибә туплый алмаган зиһенсез, кирәкле нәрсәне оныта торган врачлар һәм бер дә бармаклары эшкә шомара белмәгән, осталыкка ирешергә көченнән килмәгән агач куллы хирурглар бар шул әле.* Х.Камалов. *Безнең «Наз»ның составы егерме ел буе үзгәрмәде. Егерме ел буе чарландылар, өйрәнделәр, шомардылар, кызларның башкару осталыгы әнә шуннан килә.* К.Кәримов

5) *күч.* Күпне күрү, күп йөрү һ.б.ш. нәтиҗәсендә ачылу, кыюлану, усалланып китү; тормыш тәҗрибәсе туплау. *Егет кеше читкә китеп эшләп кайтсын, ил-җир күрсен, армиядә булсын икән! Чит җирләрдә тулай торакларда яшәсен, коллективта бераз эшкәртелсен, шомарсын икән!* М.Мәһдиев. *Йөри-йөри шомардым анысы.* М.Әмирханов

6) *күч.* Сату-алу, сәүдә эшендә тәҗрибәсе арта бару, үткерләнү, чаяру, хәйлә, мәкерле эшләргә остару. *Кемдер үзе сатасы әйберне ипләп-җайлап кына чамасыз мактый белә икән, аның сыйфатсызрак әйбере дә үтемле булып чыгачак, тизрәк сатылып бетәчәк. Сату-алу эшендә шомарган кеше андый гына хәйләне белә, әлбәттә.* Л.Хәбибуллин. *Кибет хуҗалары, базарчылар, шомарганрак приказчиклар мөсафирханә ресторанына яисә хәрчәүнәгә кереп яшертен генә пирәшләп чыгуны да онытмыйлар.* Р.Низамиев

7) *күч.* Телгә, сүзгә, сөйләргә остару. *Берсе, колхоз председателе, язгы кыр эшләренең барышы тикшерелгән пленумда харап булды. Теле-телгә йокмый торган шомарган бер ташбаш иде ул.* М.Мәһдиев. *Шушы кадәр дә тел бистәсе, сүздә шомарган, капланмыйбатмый торган чәпи ташыдай Хәнифә Галиевна һич тә әйтми-белдерми кала алмас.* Ф.Яхин

8) *күч.* Сыйфаты яхшыру, әйбәтрәк булу, камилләшү. *Пьеса шулай инде ул. Эшли-эшли шомара.* Ф.Яруллин. *Сүзлек төзи-төзи, тәмам шомарды лексикография бүлеге*

◊ **Шомарган бер тәңкә** *к.* **шомарган таш**. **Шомарган бер тиен** *к.* **шомарган таш**. **Шомарган таш** Күпне күргән, әрсез, алыш-бирешкә, хәйләгә шомарган, үткер кеше. *Әйе, Латышев – күпне күргән шомарган таш, үзе чи рус булса да, казакча да, үзбәкчә, тагы җитмәсә чувашча да сөйләшә белә икән.* Х.Камалов. *Якимов үз эшендә шомарган таш иде, ике якка да ярый белә, беркайчан өстәгеләргә каршы бармый.* Р.Габделхакова

**Шомара бару** Көннән-көн күбрәк шомару, торган саен шомару. *Ләкин тора-бара үзем дә сизә башладым: минем уйнавым чынлап та көннән-көн яхшыра, шомара бара иде.* Ә.Еники. *Егетләрнең торган саен ныграк шомара барганнары күренеп тора.* Р.Миңнуллин

**Шомара башлау** Шомарырга тотыну. *«Земля не без уродов», – дип уйлап куйды русчасы да шомара башлаган авыл малае Фәүҗәт эченнән генә.* Р.Кәрами. *Башта бик авыр иде. Аннары әкертен генә шомара башладык инде.* М.Талипова

**Шомара тору** Алдан шомару. *Кибеткә кергәнче, замдиректор булганчы шомара торсын.* И.Юзеев. *Чаңгым булса, мин дә әрәмә яннарын урап кайтыр идем. Чаңгы ярышына кадәр табаннары шомара торыр иде.* Р.Мулланурова

**Шомара төшү** Бераз гына шомару; тагын да шомару. *Менә 1977 елның 1 феврале белән билгеләнгән бер мәктүптән өзек: «Тагын да шомара төшкәнгә охшыйсың: инде образлы фикерләү дә бар синдә, кыю да, шигърияткә үз итеп тә сөйләшә аласың».* Р.Гаташ. *Ул өскә таба һәр метр саен һаман шомара төшкән бу агачны тагын да чамасыз ярсулык белән һәм тагын да көчлерәк кочаклый барды.* Ә.Мушинский

**Шомарып бетү** Тәмам, бик нык шомару. *Ул бер кулы белән ике төрәнле сабанның шомарып беткән тоткычыннан кыскан, икенче кулы белән --- атларын әйди.* Г.Әпсәләмов. *Капкадан өй баскычына кадәр яссы таш җәелгән. Алар оекчан йөрерлек, шомарып беткәннәр, ялтырап торалар.* М.Хәсәнов

**Шомарып калу** Берәр хәлдән соң шомару, шомарган хәлгә килү, шома булып тору. *Ат җигелмәгән аңа, Бер чигенә, бер бара, Юлы шомарып кала.* Табышмак. *Кичәге җылы яңгырдан соң беләү ташы кебек шомарып калган юеш сукмакны яңгыр суалчаннары тишеп шадралаткан.* Г.Сабитов

**Шомарып киту** Соңгы вакытларда шомару. *Картның хәлен сизгән кебек, тәмле телле Гүзәл сорап куйды: – Безнең әткәйдән дә матур кеше юк, әйеме, әнкәй? Әнә ул ничек түгәрәкләнеп, шомарып киткән ---.* Г.Ибраһимов. *Йөри торгач, ул балта эшенә дә, төрле сыр, сын, бизәкләр ясап, аны мебельгә ябыштыру һөнәренә дә шомарып китте.* Т.Әйди

**Шомарып җиту** *к.* **шомарып бетү**. *Бигрәк тә бер табынга утырып ашап эчкәннән соң, алар аңа инде ияләшеп тә өлгергәннәр иде. Тик әле шомарып җитмәгәннәр, --- Диләрә кебек ханымнарга бик игътибарлы булырга кирәклеген белеп бетермиләр ---.* Ә.Еники. *Шомарып җитмәгән, ахры, хәйлә белми.* Г.Сабитов

**ШОМБАЙ** *и. торки* 1) Халык әкиятенең мәшһүр каһарманы. *Шомбай боларны тыңлап торган да: «Тукта әле, боларны кызык итим», – дип уйлаган. Теге кеше юл буйлап салам чәчеп киткән, ди. Аның артыннан барган Шомбай саламнарны, җыйнап, үз юлларына чәчеп барган, ди.* Әкият. *Безнең халыкта легендар геройлар бар: Алып батыр, Хуҗа Насретдин, Шомбай.* Р.Миңнуллин

2) *күч.* Хәйләкәр, алдар кеше; аферист. *Без мулланың ни атлы икәнен дә белми идек. Үзе дә беренче очрашуда ук кисәтеп куйды, миңа хәзрәт дип мөрәҗәгать итәрсез, диде. Хәзрәт, имеш. Берәр шомбайдыр әле.* М.Әмирханов

3) *күч.* Надан, һавалы, масаеп йөрүче булдыксыз, эшлексез кеше. *Менә шуны маташтырасы иде. Ручканы борырга... бу шомбайларның көче җитми.* М.Шәрифуллин. *Әтере бөекләр исә үз исемнәре тирәсендә барган ызгыш-тартышларга һушлары китеп карап*

*торалар, шомбай, саламторханнар сырып алган мәйданга тап булуларына үкенмиләр дә микән әле?* Ф.Сафин

◊ **Шомбай бүреге** Бер үк әйберне, тышкы яктан аз-маз гына үзгәртеп, бөтенләй башка әйбер сыйфатында тәкъдим итү турында. *Үзенә генә хас хикмәтле әйтемнәре, җор җөмләләре, билгеле мәкальне Шомбай бүреге кебек кире якка әйләндереп куюы да шигъри эффект бирә.* Т.Галиуллин. **Шомбай җиләне** *к.* **Шомбай бүреге**

**ШОМБИЯ** *и. фар. бот.* Сыраҗчалар семьялыгыннан итләч сабаклы, кабырчыксыман яфраклы, башаксыман кызыл чәчәкле, көнбагыш, киндер, тәмәке, помидор һ.б.ш. кебек үсемлекләрнең тамырында үсә торган паразит үсемлек; *русчасы:* **заразиха**

**ШОМЛАНДЫРУ** *ф.* 1) Шом, шик, шөһбә салу, борчу. *Ак кар исә бүген күңелне шомландыра, ямьсез уйлар уйлата.* Н.Нәҗми. *Шәүкәтнең ---сүзләреннән шундый кайнарлык бөркелде ки, Мәрьямнең тыны кысылды. Ләкин шул ук вакытта күңел түренә боз кисәге төшкәндәй булды һәм йөрәкне шомландырып өшетә башлады.* М.Маликова

2) Куркыту, курку хисе барлыкка китерү. *Дәһшәтле кызулык бик озакка сузылды. Бу хәл һәркемне пошындырды, һәркемне шомландырды.* Н.Фәттах. *Ул чарасыз. Үз хәле хәл: кукрәгендәге утлы таш көйдерә, шомландыра, өркетә.* Н.Хәсәнов

**Шомландыра башлау** Шомландырырга тотыну. *Ләкин тора-бара очыкырые күренмәгән үлек дала аны борчый, шомландыра башлады.* Ә.Еники. *Көчле давыл вакытында дулкын юклыгы шомландыра башлады.* М.Юныс

**Шомландыра төшү** Бераз, беркадәр шомландыру; тагын да көчлерәк шомландыру

**Шомландырып җибәрү** Кинәт шомландыра башлау. *Аларның мәгърур кыяфәте Зәйтүнәнең күңелен шомландырып җибәрде ---.* М.Маликова. *Эшләр шулай гөрләп барганда, Хөсниҗиһан карчыкның тавышы барысын да шомландырып җибәрде.* Р.Газизов

**Шомландырып кую** Аз гына вакытка, кинәт шомландыру. *Машиналар янында берниндн сак юк, барысы да йоклыйлар. Әнвәрне бу хәл шомландырып куйды.* Х.Камалов. *Як-якка өелгән көрт таулары ара-тирә шомландырып куйса да, юл барыбер күңелне тынычландыра ---.* Г.Гыйльманов

**Шомландырып тору** Әле, хәзерге моментта шомландыру; даими, һәрвакыт шомландыру. *Әмма алар күздән югалсалар да, этләр тавышы шактый вакыт утар өстен шомландырып торды әле.* Г.Гыйльманов. *Менә шушы өй үзенең тынлыгы белән шомландырып тора.* З.Мурсиев

**ШОМЛАНУ** *ф.* 1) Күңелгә шом, борчу төшү, хәвефләнү, тәшвишләнү; шикләнү, шөбһәләнү. *«Бәдбәхетләр! Сез талап, дөньям минем Гүр кебек», – дип, бай малайдан шомлана.* Г.Тукай. *Торна хәбәреннән җан тынычлыгын җуйган Арыслан уяу иде, торып әнисен, хатыны белән балаларын уятты. – Нәрсәгәдер шомланам, әнкәй. Нидер булыр төсле.* Н.Гыйматдинова

2) Курку, шүрләү, куркып калу. *Пыяла аша күренгән яфраксыз шәрә агачлар кап-кара. --- Әхмәт шомлана белмәсә дә, аңа кинәт бик күңелсез булып китте.* Г.Әпсәләмов. *Атларны, арбаларны паромга төйи башладык, атлар чыгымчылап та куя, судан куркалар малкайлар, шомланалар.* Р.Газизов

**Шомлана бару** Торган саен ныграк шомлану. *Тәрәзәдән карап көлеп торган март кояшы, төтен арасыннан үтеп кереп, кешеләрнең сүрән йөзләрен яктырта, аларга караган саен, мин шомлана бара идем.* А.Гыйләҗев. *Глушконың утырыш барышын бөтенләй үзгәртеп җибәрүенә башта аптырый төшкән Гатауллин трест директорының фикере сүз сөрешеннән ачыклана төшкән саен шомлана барды.* А.Расих

**Шомлана башлау** Шомлану билгеләре барлыкка килү; шомланырга тотыну. *Карчыкны күмеп кайткач, телсез кеше шикелле берүзем уйланып утырдым-утырдым да шомлана башладым.* Т.Гыйззәт. *Тик менә тәхеткә Йосыф кахан килгәч, сарай халкы шомлана башлады.* М.Хәбибуллин

**Шомлана калу** Кинәт шомлана башлау. *Үземне шундый малай урынына куеп карыйм да шомлана калам.* Ш.Галиев. *Үз гомерендә мондый хәлне күрмәгән-белмәгән Караболак халкы чын мәгънәсендә шомлана калды, су буена төшмәс, урманга кермәс булды.* Ф.Бәйрәмова

**Шомлана төшү** Бераз шомлану; тагын да ныграк шомлану. *Һич тә курыкмыйча алдында басып торган олпат гәүдәле Мәүлетдингә карап, фельдфебель шомлана төште.* З.Зәйнуллин. *Сер ачылуга, әбисе тагын да шомлана төште һәм кызын биек таш диварлы мәгърур шәһәр капкасыннан әйдәкләп алып кереп китте.* Ф.Яхин

**Шомланып калу** Берәр сәбәптән соң шомлана торганга әйләнү. *Мин кинәт сагаеп, шомланып калдым.* З.Зәйнуллин. *Авырудан яңа терелеп килгән Гөлҗиһан да шомланып калды, йөзе җитдиләнде, уйчанланды.* Ф.Бәйрәмова

**Шомланып китү** Кинәт, көтмәгәндә шомлану. *– Я Рабби! – дип куйдым мин ирексездән. Нигәдер кинәт кенә куркып, шомланып киттем.* Ә.Еники. *Хәзер, шушы мизгелдә үк, куркыныч хөкем көткәндәй, гәүдәсе тагын да кечерәеп калды, чырае тагын да мескенләнеп шомланып китте.* З.Хөснияр

**Шомланып кую** Аз гына вакытка, беразга гына шомлану хисе тою. *Алексей, позициягә кайтып җитәрәк, Мулла машинасын танып шомланып куйды.* Х.Камалов. *Чардуган янына атлы арба килеп туктагач, Васфикамал шомланып куйды.* М.Мәһдиев

**Шомланып тору** Даими, һәрвакыт шомлану; әле, сөйләү моментында шомлану. *Болай да төрле шик-уйлардан борчылып, шомланып торган күңеле аның кеше каргышыннан, кеше бәддогасыннан чынлап та курка калды.* Ә.Еники. *Өнемме бу, әллә төшемме дип беравык шомланып торганнан соң, коточкыч һәлакәткә дучар булуыбызны хәтерләдем ---.* С.Сабиров

**ШОМЛЫ** *с.* **1.** 1) Куркыныч, үзендә шом, куркыныч яшеренгән, курку хисе тудыра торган. *Көнбатышта бөтен офык буен кан төсле кызыл шәфәкъ каплаган. Каберлектә генә була торган ниндидер авыр, шомлы тынлык.* Г.Әпсәләмов. *Ул көннең киләсен белеп, сискәнеп көтте Гөлнар. Күңеле ямьсез сизенү белән нииндидер шомлы көнне көтте.* А.Әхмәтгалиева

2) Хәвефле, хәтәр, шом белдерә торган. *Кешеләрне салкыны, ачлыгы, кием-салым мохтаҗлыгы, фронттан килгән шомлы хәбәрләре, күз яше түгүләр белән җәфа чиктергән кырык өченче елның кышы үтеп китте.* Г.Галиев. *--- прокурор һич уйламаганда капитан Чураевтан хат алды. Нәрсә дип әйтергә, күңелсез һәм шомлы хат иде ул.* Р.Мирхәйдәров

3) Кайгылы, борчулы, фаҗигалы. *1941 елның көзге, шомлы көннәрендә аларның төркем-төркем булып Яңавыл читендә марш атлап йөрүләре әле булса күз алдымда тора.* Н.Фәттах. *Әмма бу шомлы елларның катлы-*

*катлы сынавы әле моның белән генә дә чикләнмәгән икән.* К.Тимбикова

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Шом салып, шик тудырып. *Ул, куркынып, янында баручы һәм хәзер ничектер ят, шомлы булып күренгән Григорийга текәлде.* А.Расих. *--- алар мине клубка чакырдылар, эссе кояшлы якты көн уртасында клуб эче караңгы, ятим, шомлы булып тоелды.* М.Мәһдиев

2) Куркытып, хәвефле итеп. *Бөтен җирдә биек-биек агачлар, агачларда шомлы итеп ябалаклар кычкыра.* Ф.Яруллин. *Гөлҗиһанга ул вакытта бик куркыныч булып киткән иде. Чөнки Таһирҗан бабай да бик шомлы сөйли, күл буендагы җимерек сыннар да аңа бөтенләй башкача күренә башладылар.* Ф.Бәйрәмова

**ШОМЛЫК** *и.* 1) Яман, начар, әшәке нәрсә; явызлык. *Землянка яңа гына җылына башлаган, аның эче тулы ачлык һәм шомлык. Караңгы һәр почмагына өшегән үлем кереп утырган да, ящеренеп тә тормыйча, тешләрен ыржайтып каткан килеш басып тора.* З.Зәйнуллин. *Ә теге шомлык, чакыруны да көтмәстән, плакатын тагын да югарырак күтәреп, өерне яра-ера, үзе ыргылды трибунага табан.* Ф.Баттал

2) Бәхетсезлек, бәла. *Өрәкләрдә юк мәрхәмәт: түбән хис, бер өмет юк; Я Рабби, каян дөньяда бу куркыныч, бу шомлык?!* Р.Гаташ. *Кич куера шымшым гына. Якты тынлык әйләнмәгән Төннең кара шомлыгына.* Р.Бикбаев // Афәт, дәһшәт, куркыныч. *Житмеш йортны яндырдым, Җитмеш җитеп килгәндә. Явырдан явырым калмады, Яу башлар ирем калмады ---. Туктамыш чапса, кем калды? Ни шомлыкка тарыдым? – Аны әйтеп Шаһ Тимер, Күмердәй кара киселде.* Дастан. *Халикъ хаҗи улларына әйтә икән: «Балалар, магазинны ябыйк, булмаса. Бу хәтле баю шомлыкка булмагай иде», – дип әйтеп әйтә икән.* Ш.Камал. *Илдә – тынлык, юлда – шомлык... Гасырлар кубарылган, Мәртәбә тапкан галимнәр Ахмакка чыгарылган...* Ф.Яхин

3) Нинди дә булса явызлыкның яки бәхетсезлекнең сәбәбе, чыганагы. *Нинди каһәр суккан шомлык аның кешелек сыйфатларын бетергән? Ул шомлык безнең күз алдыбызда, ул – иске татар тормышы.* Ф.Әмирхан // Нәрсәнең дә булса начар тәэсире, шаукымы. *Сез нәҗесләрнең шомлыгы аркасында мондый бәхетсезлекләргә очрадым.* Г.Камал. *Кеше бәласенә шатланмыйлар, шулай да Саниянең ачы күз яшьләре суктымы үзен, әллә аның чыннан да Таймасның үлемендә катнашы булып, шуның шомлыгымы?* З.Мурсиев

4) Эчтән күңелне борчып торган тынычсызлык, курку, шүрләү хисе. *Җиңү якынайганы сизелсә дә, халык билгесез бер шомлыкта яши иде.* Р.Батулла

5) *сөйл.* Җиңелчә тиргәнү, ачулану сүзе; ярату, ошату, хуплау яисә канәгатьсезлек, ризасызлык, үпкә кебекләрне белдерә. *Бакчалар бик күңелләнәнде, кара карлыган котырып уңды, яфрагы күренми шомлыкның, билләһи.* А.Гыйләҗев. *Кирәк бит, таш бер казның башына килеп тигән. Аның өчен күрше карчыгы каргады Габделнурны. – Әй шомлык, олтырак бит, чабата чырай, яхшыдан яман туган нәрсә.* Р.Кәрами

◊ **Шомлыкка каршы** Нәрсәгә дә булса үкенеч белдереп әйтелә; ни үкенеч, бәхетсезлеккә, кызганычка. *Аларның күбесенә, шомлыкка каршы, Алла матурлык биргән.* Г.Коләхмәтов. *Ә менә... Шомлыкка каршы, Ансы юк иде... Фигура булгач булсын ул, Эредән, дәүдән булсын – Президиумга сайларлык Мәһабәт гәүдәң булсын!* Ш.Галиев

**ШОМЛЫКЛЫ** *с.* Начар, яман. *Нигезгә этнең күмелүен ишеткәч, Галимбик уйга калган. Эт күмелүнең шомлыклы бер эш булуын хәтеренә китергән.* Риваять

**ШОМЛЫЛЫК** *и.* Шомлы булу. *Караңгыда шул ерактагы кызыл ялкын шәүләсе сыек кына булып солдат йөзләренә килеп куна, күзләрен ялтыратып куя, һәм ниндидер хәтәр шомлылык җилекләргә хәтле үтеп керә.* Х.Камалов. *Бүлмәдә һәрнәрсә --- артык саллы, авыр булып күренде. Ниндидер кырыслык, шомлылык бар кебек иде биредә.* М.Маликова

**ШОМПОЛ** *и. нем.* 1) Утлы коралның көпшәсен дары яну калдыкларыннан чистарту яки майлау өчен кулланыла торган металл яки агач чыбык. *Мылтык көпшәсен шомпол белән чистартканнар (шомпол беренче гади мылтыкларны корган вакытта да кулланылган, көпшә эчендә утырып калган пуляны да шомпол ярдәмендә төртеп чыгарганнар).* А.Тимергалин. *Шундый нарядларның берсеннән йөреп кайткач, карабинымны җәһәт кенә чистартып куюю теләге белән, шомполның юан башына чүпрәк урап, карабинның көпшәсенә тыктым.* Р.Сафин

2) Җәза бирү, суктыру өчен кулланыла торган шундый тимерчыбык; шундый җәза. *Ишек алдына алып чыгыгыз да йөз шомпол бирегез!* Т.Гыйззәт. *Камчы белән суктырылган, шомполлар белән кыйналган старшиналарның да хәле җиңел түгел ---.* В.Имамов

**ШОМПОЛЛАУ** *ф.* 1) Шомпол ярдәмендә көпшәне чистарту һәм майлау. *Карабинны шомполлау*

2) Шомпол белән суктыру

**ШОМРАЙТУ** *ф.* Нәрсәдән дә булса сагаеп, колакларын торгызу. *Акбай, хуҗасын сагынса да, тамагына каба. Синең машина тавышын әллә каян ишетеп колагын шомрайта, хайванкай.* Н.Гыйматдинова. *Берничә тапкыр кара айгыр өер башының бияләренә «бәйләнде». Хәзер көтүченең юклыгын абайлагач, күзләрен алартты, Күктимер ягына сөзеп карап ала, тагы колакларын шомрайта.* Р.Камал

**Шомрайтып алу** Азга гына, тиз генә шомрайту. *Ара-тирә алашам колагын шомрайтып ала: андый чакта, тәннәремне кымырҗытып, йөрәккә шом төшә.* Х.Сарьян

**Шомрайтып кую** Көтмәгәндә, кинәт шомрайту; бер тапкыр шомрайту

**Шомрайтып тору** Озак, даими рәвештә яки сөйләү моментында шомрайту. *Каршыдагы йортның капка төбендә колакларын шомрайтып торган көчек, бар көченә ләң-ләң килеп, машинаны куа китте.* Р.Вәлиев. *Берара уйланып, колакларын шомрайтып торганнан соң гына игътибар итте: печән тапталмаган, сыер эзе бөтенләй юк!* А.Фәләх

**ШОМРАЮ** *ф.* 1) Янаган куркынычны сизенеп сагаю, һөҗүмгә яки качуга әзер хәлгә килү (ат, эт һ.б. хайваннар тур.). *Ат ачудан башын чөя, шомрая, авызындагы башакны чәйнә.* С.Рәфыйков. *Берзаман сыерлар шомраеп, мөгезләрен күккә күтәреп, бер якка савылып күчә башладылар.* А.Гыйләҗев

2) Игътибарны арттыру, сагаю, саклык-сизгерлек тойгысын көчәйтү (кеше тур.). *Пәйгамбәрнең «Өммәтем өчен Дәҗҗалдан бигрәк азгын имам куркыныч» дигән сүзләрен дә әйтергә кушкач, озын торыклы швейцар, шундук шомраеп, ләкин күп сорашып тормастан, постын ташлап, имам хәзрәт катына элдерде.* А.Тимергалин

**Шомраеп калу** Кинәт шомраю; берәр сәбәптән шомраю. *Рәүф чылбырны һәм йозакны кулына алды. – Димәк,*

*бер сулагай бәндә безнең көймәдә тонлә йөреп маташкан. Кем? – Шомраеп калдылар. Торналыда кем сулагай?* А.Тимергалин. *Малай әллә аптырап, әллә шомраеп калган иде: үзен кочакларга тулы ирек биреп, тып-тын калды, аваз-өн чыгармады.* А.Әхмәтгалиева

**Шомраеп тору** Озак, даими рәвештә яки әле, хәзер шомраю. --- *колын артын сикертә-сикертә, уйнаклап чабып килеп җитә, шомраеп торган әнкәсенең имиләренә иркәләнеп, борынын төртә* ---. А.Гыйләҗев. *Бер генә мизгел ул нәрсәдәндер шомраеп торды, аннары кешнәмәде-нитмәде, тонып, Айнурга таба чапты*. Ф.Садриев

**ШОМЫРТ** *и.* **1.** 1) *бот.* Гөлчәчәкләләр семьялыгыннан тәлгәшкә тупланган хуш исле вак ак, баллы чәчәкле агач; муел. *Анда бүре дә, җәен дә, чоңгыл да юк – анда җәй дә, кыш та чәчкә ата торган әрәмәлекләр, карлыганнар, шомыртлар, тагын, тагын әллә ниләр.* Ә.Баян. *Анда нинди генә агачлар үсми: миләштер, шомырттыр, баландыр.* Н.Хәсәнов

2) Шул агачның авызны бөрештерүчән, эчендә каты төше булган кара җимеше. *Мин әле Женяның тел төбен аңламыйм: – Бу вакытта нинди җиләк булсын? – Җиләге булмаса, шомырты булыр. Изелеп пешкән!* Р.Габделхакова. *Эре-эре шомыртлар нык пешүдән шәмәхәләнә төшкән, тик тәлгәшләре пәрәвез белән капланган.* Н.Әхмәдиев

**2.** *с. мәгъ.* Шуның өлгергән җимеше төсендәге, чем кара, кап-кара. *Шомырт түшле сыерчыкларга кадәр [саранчаларны] берәмләп чүпләгәннәр.* А.Алиш

**ШОМЫ́РТ КАРА** *с. к.* **шомырт 2.** --- *башына яулык та ыргытып өлгермәгән кыз бала, ачык изүләрендә, иңенә таралып төшкән шомырт кара чәчләрендә җил уйнатып, Канәгать артыннан көнчыгышка чаба иде.* А.Хәлим. *Бигрәк җитез ага шул безнең Кара чишмә. Әлеге шомырт кара майлы бөрчекләр Тау-бабайның каны шикелле тоела иде миңа.* Г.Рәхим

**ШОМЫРТЛЫ** *с.* 1) Шомырт (*1 мәгъ.*) күп үскән, шомыртка бай булган. *Көмеш Чишмәнең кояш чыккан урамында, аның да иң беренче өендә, иртәнге көтү авыл белән хушлаша торган шомыртлы тау янында яшәп ятулары.* Р.Газизов. *Шомыртлы әрәмәләрне, җиләкле урманнарны, кыр казлары йөзә торган камышлы күлләрне үз күзләрем белән күрәсем килде.* Р.Габделхакова

2) Шомырт (*2 мәгъ.*) кушкан, шомырт салып әзерләгән. *Әбекәй --- өстәлгә төелгән шомыртлы кабартмалар куя.* Н.Шәрифуллин. *Йөрәксенүен белдермәскә тырышып, тамагын кырды, калагын әле чияле, әле шомыртлы майга сузды.* Т.Гарипова

**ШОМЫРТЛЫК** *и.* Шомырт агачлары күп үскән урын. *Су буендагы таллыкларга ышыкланып, шомыртлыкка кадәр барды да, туктап, караңгы төшкәнне көтте Фазыл.* Н.Әхмәдиев. *Яр буйларында ук үсеп утырган агачлар арасыннан кереп китәсең дә шомыртлыкларга --- барып чыгасың.* Р.Рахман

**ШОҢКАР** *и. зоол.* Лачын кошлар семьялыгыннан оясын кыяларда, тау битләрендә, ачык сөзәклекләрдә кора торган, сапсанга ошаган ерткыч кош; ау лачыны; *русчасы*: **кречет**. *Очырганы бөркет кошы, Чөйгәне шоңкар булган.* Дәрдемәнд. *Таш кыялар ышыгында, киң далалар кочагында, Урал шоңкарларыдай иректә яшәрбез, диде.* Г.Сабитов

**ШОП** *и. ингл.* Гадәттә чит ил әйберләре сатыла торган кибет

**ШОП-** *кис. [ш]* авазына башланган кайбер сүзләр алдында килеп, артыклык дәрәҗәсе ясый торган кисәкчә. *Агар-акмас кына ага иде ул инеш. Өсте көзге кебек шоп-шома.* Г.Әпсәләмов. *Шәрәф фронттан бик әйбәт, апак, шоп-шома немец кәгазьләре алып кайткан булган.* Л.Ихсанова

**ШО́ПИНГ** *и. ингл.* Сәүдә үзәкләрендә, зур кибетләрдә йөреп вакыт үткәрү һәм товарлар (кием-салым, аяк киеме, косметика, аксессуар һ.б.) сатып алу. *Ике атна инде ресторанга барган юк, шопингка чыкмыйм.* Л.Әбүдәрова. *Бүгенге шопингтан соң миңа ир-ат игътибары әллә ни кирәкми дә инде...* Идел

**ШОПТЫРДАТУ** *ф.* 1) *к.* **шаптырдату**

2) *к.* **шопырдату**. *[Хатыны] Кәримнең шоптырдатып аш ашаганын ишетеп ята.* Г.Ахунов

**Шоптырдатып алу** Аз гына вакыт, бер тапкыр гына шоптырдату

**ШОПТЫРДА́У** *ф. к.* **шаптырдау**

**Шоптырдый башлау** Шоптырдарга тотыну

**ШОПЫРДАТУ** *ф.* Шопыр-шопыр итеп суырган тавыш чыгарып ашау, эчү. *Ул барып җиткәндә, ипи кунасында кибән башлар беткән, малайларкызлар, озын такта өстәлгә сырышып, тары өйрәсен шопырдаталар иде.* А.Гыйләҗев. *Тешләре төшкән, яңаклары утырган карт исә рәхәтләнеп шопырдата, йомшак пилмәнне ура иде.* Казан утлары

**Шопырдата башлау** Шопырдатырга тотыну

**Шопырдатып тору** Әле, хәзерге вакытта шопырдату

**ШОПЫРУ** *ф.* Аш яки сыеклыкны савыттан зур йотымнар белән характерлы тавыш чыгарып суырып эчү. *Мөби токмачлы ашны тирләгәнче шопырды.* М.Мәһдиев. *Хаким, иренен очлайтып, чәй шопырды.* Н.Гыйматдинова

**Шопыра башлау** Шопырырга тотыну. *Хәлим, булары бөркелеп торган тәлинкәсенә якын иелеп, тәмле токмачны шопыра башлады.* Г.Гобәй

**Шопырып бетерү** Тулысынча, барысын да шопыру; шопыруны тәмамлау. *Юка гына бер телем ипи белән кәбестә шулпасын минут эчендә шопырып бетерәбез.* Т.Нурмөхәммәтов

**Шопырып тору** Әле, хәзерге вакытта шопыру

**ШО́ПЫР-ШОПЫР** *иярт. к.* **шапыр-шопыр**. *Кияү, чык-чык китереп, калай кашыгын таш тәлинкәгә бәрде. Шопыр-шопыр аш чөмерде.* М.Мәһдиев

**ШОР** *и.* Телләре төрки телләр семьялыгына караган, Кемерово өлкәсендә, Хакасия һәм Алтай Республикаларында яшәүче, тәңречелек һәм православие динендәге төрки халык һәм шул халыкның аерым бер вәкиле. *Шуннан бу сүз төрле ыруда төрле мәгънәдә урынлашып калган: төрекләрдә – тагри (күк), шорларда – тангри, теләветләрдә – танара (күк), татарларда – таңгри (мәгъбүд) һәм диңгез (диңгез).* Х.Бәдигый

**ШО́РНИК** *и. рус* Ат дирбияләре ясау һәм төзәтү остасы. *Дөрес, хезмәте аның зурдан түгел, ул бары өендә шорник булып эшли: Әхмәтвәли китереп биргән машина каешларын ялгый, чи каештан камыт баулары кисә, сүтелгән бөятләрне тегеп утыра.* Ә.Еники. *Һәркайсыгызга атлар беркетербез, икешәр ат, ике төрәнле сука белән җир сукаларсыз. Ел коры килә, яз иртә, ат ызбруйларын тикшерерсез, камыт баулары өзелсә, шорниктан тектерербез, йөгәннәрегезне, дилбегәне барларсыз ---.* Г.Ахунов

**ШО́РНИКЛЫК** *и.* Шорник эше, шорник һөнәре. *Муса абзый камытияр төзәтеп, шорниклык һөнәре белән көн күргән.* Социалистик Татарстан

**ШОРТ-ЛИСТ** *и. ингл.* Премия, бүләк, вазифа һ.б.ш.га тәкъдим ителгән

кандидатларның озын исемлегеннән кыскартып алынган исемлек

**ШОРТ-ТРЕК** *и. спорт ингл.* Тимераякчыларның әйләнә буенча кыска ераклыкка (111 м) ярышы. *Спорт уеннары сигез төрдә үткәрелә: биатлон, тау чаңгысы спорты, чаңгы, трамплиннан чаңгыда сикерү, фигуралы шуу, сноуборд, хоккей һәм шорт-трек.* Әгерҗе хәбәрләре

**ШО́РТЫ** *и. ингл.* Балаклары тездән югары, кыска чалбар төре. *Гөлчәчәк, җиңсез матур күлмәк, шорты һәм аякларына әллә кайдан кычкырып торган кроссовка кигән малайны танып, югалып киткәндәй булды.* З.Хөснияр. *Коридорда --- тәненә баштанаяк сурәт төшергән адәмнәр йөри. Өсләренә дә кимәгәннәр ичмасам, кыска шортыдан гына, пляждамыни!* И.Сиражи

**ШОССЕ** *и. фр.* Автотранспорт йөрү өчен таш түшәп асфальт яисә бетон җәеп эшләнгән киң юл. *Тимерьюл белән рәттән уза торган шосседан машина тавышы ишетелде ---.* А.Гыйләҗев. *Авылның уртасында бер мәчетләре урнашкан, әгәр мәчетләре авылның шоссе ягында булса, узган-барганда юлдан күренеп торыр иде, ә болай юлдан мәчет күренми.* М.Мәһдиев

**ШОТЛАНД** *и.* Гэль, инглиз, шотланд телләрендә сөйләшкән, христиан динен тоткан, Шотландиядә яшәүче төп халык һәм шул халыкның бер вәкиле. *Англияне Шотландия кешеләре басты. Лондонда вә башка зур шәһәрләрдә ниндәй генә зур эшнең башындагы кешене карасаң, шотландияле булып чыгадыр.* С.Максуди

**ШОТЛА́НДИЯЛЕ** *и.* Шотландиядә яшәгән яки чыгышы шуннан булган кеше

**ШОТЛА́НДКА** *и. рус* **1.** Төрле төстәге җепләрдән шакмаклап сугылган киҗе-мамык, ярымйон яки ефәк тукыма. *Әни белән бертуган апага дигән алъяпкычлык шотландка, җизнигә дигән ефәк майка, --- миңа хат язучы Оркыя күршегә исле сабын белән гәрәбә алдан әзерләнеп куелган иде.* М.Юныс

**2.** *с. мәгъ.* Шундый тукымадан эшләнгән, тегелгән. *Хәзер ул --- чалбар өстеннән чыгарып киелгән ике чабулы шотландка күлмәктән генә иде инде.* М.Әмир

**ШО́У** *и. ингл.* Телевидение, эстрада, цирк һ.б.ш.да төрле күңелле, кызык чараларга бай булган зур тамаша. *Ә менә Дамир, үзенчәлекле бәйрәм уздырып, Кремльдә, бигрәк тә Сөембикә манарасында Сөембикә образын күрсәтүе белән һәм шул ук вакытта шундый тамаша, хәзергечә әйтсәк, шоу оештыруы белән бөтен Казанны шаулатты.* Р.Вәлиев. *Хәзер исә шоулар, тамашалар заманы. Эстрада җырчысы тавыш белән генә берни дә кыра алмый. Кыйммәтле аппаратура, заманча музыкаль бизәлеш, кием-салым, яктылык куелышы, тамашачы белән мөнәсәбәт...* Р.Миңнуллин

**ШОУ-** *ингл.* Кушма сүзләрдә «күңел ачу чаралары, эстрада тамашасы белән бәйле» мәгънәсендәге беренче кисәк (мәс., *шоу-бизнес, шоу-группа*)

**ШОУ-БИ́ЗНЕС** *и. ингл.* 1) Төрле тамашалар, күңел ачу чаралары оештыру белән бәйле эшмәкәрлек, тамаша бизнесы. *Шоу-бизнес дия-дия, җитәкчеләребез, җырчыларыбыз, хәтта тамашачы үзе дә акны карадан, талантлыны талантсыздан аера алмаслык хәлгә килде.* Г.Бәйрәмова. *Татар шоубизнесында зур рольне Оскар Усманов уйнады, аңа күп артист үз популярлыгы белән бурычлы.* Л.Заһидуллина

2) Фильм, фонограмма, аудиовизуаль продукция җитештерү, тиражлау, рекламалау һәм күпләп сату эше

**ШОУ-ГРУ́ППА** *и. ингл.-нем.* Эстрада, күңел ачу тамашасын күрсәтүче артистлар төркеме

**ШОУМЕН** *и. ингл.* Башлыча телевидениедә музыкаль программа, концерт, викторина, төрле тамаша һ.б.ш.ны алып баручы, кайчакта үз номерлары белән актив катнашучы кеше. *Бер олуг шоуменыбыз да әнә хәзер, бүтән җырламыйм, сөйләмгә генә күчәм, алай шәбрәк, ди икән.* Ә.Хәсәнов. *Танылган Россия шоумены Павел Воля белән якташыбыз Ләйсән Үтәшеваның туе хакындагы хәбәр интернет челтәрендә --- пәйда булды.* Акчарлак

**ШОФЁР** *и. фр.* Автомобиль йөртүче. *Зур кузовлы йөк машинасының кабинасында урын булмады: шофёр янында кызмача иптәше дә бар иде.* М.Мәһдиев. *Шофёр, тизлек рычагын тартып, газга басты һәм машина --- бар булган тизлегендә Азнакайга очты.* Н.Әхмәдиев

**ШОФЁРЛЫК** *и.* Шофёр эше, шофёр һөнәре. *Мин менә шулай сорау арты сорау биреп, Рәүфнең биш бала үстерүен, --- Вилданның шофёрлыкка укуын --- белеп алдым.* Т.Әйди. *Мин шофёрлыктан башка һөнәрне күз алдыма китерә алмадым.* Ф.Яруллин

**ШӨБҺӘ** *и. гар.* 1) Кем турында булса да, гаепле яисә начар булырга тиеш, мөмкин, дигән уй; шик, икеләнү. *Мөнәвәрә хатын, шаһзадә аягына егылып: – Әфәндем, инсафлы һәм кешелекле иканегезгә шөбһәм юк, – диде.* К.Насыйри. *Легиондагылар Берлинда эшләүчеләрнең һәммәсенә шөбһә белән карадылар, шпион дип уйладылар.* Г.Солтан

2) Тәшвиш, шом; шик, ышанмау хисе. *Үзенең алданганлыгында һич шөбһә юк иде.* Г.Камал. *– Күңелгә шөбһә керде, – диде Вәсим, кызны иңеннән кочып. Сөнбел туктап, никтер, як-ягына карап куйды. – Нинди шөбһә?! – дип пышылдады ул. – Бернинди шик-шөбһәгә урын юк. Мин сине яратам, Вәсим!* З.Хәким // Кемгә яки нәрсәгә дә булса ышанмау хәле; курку хисе. *Ул һәр көн миңа Йосыфҗанның җасуслыгы хакында тукый. Башкалар да шуны тәкрарлыйлар. Башта шөбһәдә булсам да, бер вакыйга мине бик уйлатты.* Г.Ибраһимов // Вәсвәсә, коткы. *Иртәнге якта солдат Галияр, синең урыныңа рәис булам, дип, күңеленә шөбһә салды ---.* М.Хуҗин. *Күңелемне кара шөбһә булып Талый, талый изге көнләшү.* Р.Харис

◊ **Шөбһәгә алу** Ышанычсыз санау, ышанмау; шик белдерү. *1219 елны Чыңгызханның Урта Азиягә явы алдыннан Бөек Монгол империясенең тәхет варисы мәсьәләсе карала һәм сарайда шул вакытта Чагадай белән Җучи арасында низаг чыга: беренчесе үзенең абыйсын, ягъни Җучины, «меркит әсирлегенең мирасы» дип атый һәм шулай итеп аның Чыңгызханның генетик варисы булуын шөбһәгә ала.* Д.Исхаков. **Шөбһәгә төшү** Шиккә калу, шикләнү, шөбһәләнү. *Шунда кичә генә күрше хатыннан сатып алган майдан пыяла кисәге чыккан. Әни шөбһәгә төшкән; ике йомарлам майның берсен ул апага биреп җибәргән булган.* М.Мәһдиев. *Аңа саксызрак кагылудан курка, тиешле-тиешсез сүз әйтмәгәе, дип шөбһәгә төшә.* Р.Кәрами

**ШӨБҺӘ́ ИТҮ** *ф. иск.* Шөбһәләнү, ышанмау. *Яңадан сугыш булган тәкъдирдә дошманнарны җиңәчәкләрендә төрекләр шөбһә итмиләр.* Г.Камал. *Мин сез утырткан чәчәк түтәлләренең матурлыкларына шөбһә итмим.* К.Тинчурин

**ШӨБҺӘЛӘНҮ** *ф.* 1) Нәрсәгә дә булса ышанып җитмәү, тулы ышаныч булмау, икеләнү, шикләнү. *Шөбһәләнде кыз, икеләнде һәм көннәрнең берсендә аның күз алды караңгы төндә яшен уйнагандай яктырып китте: әллә ярат-*

*мыймы соң аны Җәмил?!* А.Гыйләҗев. *Сәяхәтче башта Көмешкәйнең тәкъдименә икеләнеп, шөбһәләнеп карады.* К.Тәхау

2) Курку, шүрләү; шомлану. *Офицер, мөгаен, бу пәһлеван дуласа, өчебезнең дә башына җитмәгәе, дип тә уйлап алгандыр, шөбһәләнгәндер.* К.Миңлебаев. *Хәлимә гомер буе аның белән очрашудан куркып яшәде. Ул турыда уйласа да, тәннәре чымырдап, тыны буыла иде. Эзләп табар да, иң газиз әйбереннән аерып, йөрәгеннән телгәләр дип шөбһәләнде.* Г.Әдһәмова

**Шөбһәләнә башлау** Шөбһәләнергә тотыну. *Мәрфуга абыстай кияү муллага азрак булмаса ярар иде дип шөбһәләнә башлады.* Г.Исхакый. *Болай да соңгы вакытларда малаеның акылына зәгыйфьлек килмәдеме дип шөбһәләнә башлаган әти-әнисе ни әйтер бу эшкә?* А.Гыймадиев

**Шөбһәләнә калу** Кинәт кенә шөбһәләнә башлау. *Шәйхи әфганлыларның болай җанланып китүләреннән шөбһәләнә калды.* Ш.Усманов

**Шөбһәләнә төшү** Бераз шөбһәләнү; тагын да ныграк шөбһәләнү. *– Ничек өйдән? – Равил шөбһәләнә төште, маңгаена тир бәреп чыкты. – Әлмәттәнме?* Җ.Рәхимов. *Командир көттереп кенә өстәп куйды: – Сезне Гирш Ольккеницкий канаты астына җибәрергә тәкъдим итәләр. – Кайсы төшкә? – дип аңлашмыйча да, шөбһәләнә төшеп тә сорады Шамил.* З.Фәтхетдинов

**Шөбһәләнеп алу** Бераз, вакытлыча шөбһәләнү кичерү. *Остазлар да, алар янәшәсендә без дә: «Әдәбиятка шигырь-хикәя язучы яшьләр килми!» – дип, чаң сугар чиккә җитеп шөбһәләнеп алдык.* Иделем акчарлагы

**Шөбһәләнеп калу** Нindидер сәбәптән соң шөбһәләнә башлау. *Бәһрам шаһзадә үз туфрагына аяк басуга шөбһәләнә калды.* Н.Фәттах. *Үз гәүдәм дөрес түгел мәллә, дип шөбһәләнә калдым.* Ш.Галиев

**Шөбһәләнеп китү** Кинәт, көтмәгәндә шөбһәләнү. *Ул, миңа карамаенча: – Син марҗалар берлә әллә нинди оят эшләргә солдаттан өйрәнеп кайткан! – диде ---. Минем күңелем шөбһәләнеп китте.* Г.Исхакый

**Шөбһәләнеп кую** Бераз гына шөбһәләнү. *Әллә инде бәхете артык зур булгангамы, әллә инде бүтән бер сәбәптәнме, кайчакларда Диләфрүз үз бәхетенең зурлыгыннан үзе үк куркып, аның ныклыгына шөбһәләнеп куя иде.* Г.Әпсәләмов

**Шөбһәләнеп тору** Күпмедер вакыт шөбһәләнү; әле, хәзер, сөйләү моментында шөбһәләнү. *Тукта, партком секретаре белән төптәнрәк сөйләшү өчен, бик тә җай чыгып тора түгелме? Әйе, ни пычагыма куркып, шөбһәләнеп торырга соң?* Э.Касыймов

**ШӨБҺӘЛЕ** *с.* **1.** 1) Шикләнүле, сагаюлы, кемгә яки нәрсәгә дә булса ышанып бетмәгән. *Бел: песинең юньлесе ике генә төсле була аның. Ә бу хәерсез өч төстә иде: ак та, кара да, сары да! Шундук саф күңелемә шөбһәле уй иңде бит: әһә, димен, мөгаен, юньле хәл түгел бу, казага булыр!* А.Гыйләҗев. *Шәмтиев тынычсызлана башлады. Ишек төбендә утырган ОГПУ вәкиленә шөбһәле караш ташлап алды.* Ф.Сафин

2) Ышанычсыз, ышандырмый, шик тудыра торган, шиккә урын калдыра торган. *Мулланың сүзләре икеле генә түгел, бөтенләй шөбһәле күренде.* Г.Ибраһимов. *Фәхрине үтерүдә гаепләнеп, күп кенә шөбһәле дәлилләр аркасында кулга алынган Садыйкның шәхси тарихлары әнә шулай килгән.* Г.Нигъмәти

3) Шик астына алынган, шикле. *Башка берничә шөбһәле адәмнәр белән бергә Мәрьям дә зинданга алынды.* Г.Ибраһимов. *Столыпин реакциясе чорында шөбһәле кешеләрне эзләүләр бик көчәйгәнлектән, бу минем өчен бик табигый иде.* С.Кудаш

4) Шиге булган, шикләнгән. *– Рәшидә апа, ишеккә килсә, башына көрәк белән тондырмассызмы? – Ю-ук, – дип, теләмичә генә көлемсери шөбһәле хатын. – Болай да ялгыш бит, аңышмыйча...* Р.Камал

4) Куркынычлы, хәтәр. *Аның шөбһәле сүзләрен ишетеп, без бик каты шүрләдек...* А.Гыйләҗев. *Без ерактанрак моны күрдек тә, монда ни дә булса бер шөбһәле эш бар дип якынрак килдек.* Ф.Вәлиев

**2.** *рәв. мәгъ.* Куркытып, хәвеф белән, шомлы итеп. *Аның беркайчан да болай шөбһәле итеп үз бүлмәсенә бикләнеп җырлаганы юк иде.* М.Мәһдиев. *Тана ярга чыгарга азаплана, шөбһәле мөгри...* А.Хәсәнов

**3.** *хәб. сүз мәгъ.* Икеле, шикле, ышанычсыз. *[Берәү:] Бундый эшләр соң, хәзрәтләр, пәйгамбәремез заманында булганмы инде? [Хәзрәт:] Анысы шөбһәле инде.* Г.Исхакый. *Башка вакытта ачык йөз белән каршылаучы мөдиремнең шулай сер саклап азаплануы бик шөбһәле иде.* А.Гыйләҗев

**ШӨБҺӘСЕЗ** *рәв.* **1.** 1) Анык, төгәл билгеле, шик тудырмыйча. *Башта ук бер нәрсә миңа шөбһәсез кебек тоелды: мәрхүм Башкортстан җирендә туып үскән булырга тиеш (Уфа дигәне шуны аңлата булса кирәк).* Р.Мостафин

2) Икеләнмичә, шикләнмичә. *Мин яратам сине тулы килеш, Вакланусыз, шиксез, шөбһәсез.* Р.Сәйфетдинов. *Мин инде аның сихерче түгел икәнлеген белә идем. Шунлыктан һичбер шик вә шөбһәсез алгы капкаларын ачтым.* Ф.Яхин

**2.** *с. мәгъ.* Ышанычлы, шик тудырмый торган. *Алар – тарихыбызның, телебезнең борынгылыгын аңлата торган шөбһәсез дәлилләр.* Ф.Гарипова

**3.** *кер. сүз функ.* Һичшиксез, бернинди шиксез, әлбәттә. *Шекспир, Мольер, Островскийларның театр әсәрләре, шөбһәсез, минем драма әсәрләремнең техникасына тәэсир иттеләр.* Г.Исхакый. *Шөбһәсез, мин башка нәрсәләрем белән сине дә, сиңа булган мөнәсәбәтне дә югалткан идем.* Г.Ибраһимов

**4.** *хәб. сүз мәгъ.* Шиксез, анык, төгәл билгеле. *Бу бәндәнең монда юньлегә килмәве шөбһәсез. Ул Апанаевларның хәзинәсен эзләп йөри, әлбәттә.* Г.Әпсәләмов

**ШӨГАРА** *и. гар. иск.* Шагыйрьләр. *Һәр милләтнең шөгарасы – шул милләтнең теленең сакчысы вә төзәтүчесе.* Ф.Әмирхан

**ШӨГЫЛЬ** *и. гар.* 1) Нинди дә булса эш, хезмәт. *Нәселдән нәселгә күчеп килгән бер шөгыльләре бар – балыкчылык.* А.Фәләх. *Аңа сарык бәрәннәре белән уйнау, --- каз бәпкәләрен су буена төшерү кебек шөгыльләр кызыграк тоелды.* М.Яһудин

2) Күңелне биләү, вакыт үткәрү өчен башкарыла торган нинди дә булса эш, хәрәкәт; игътибарны тотып торырлык мәшгульлек; хобби. *Нәрсәдер эшләргә кирәк иде, ләкин күңеленә канәгатьләнү китерерлек шөгыль тапмады.* М.Хуҗин. *Борһанның бер күптәнге яраткан шөгыле, заманча әйтсәк, «хоббие» бар иде. Ул «Аларны милиция эзли»гә кагылышлы төрле фотосурәтләр җыйнау белән мәшгуль иде.* Х.Ибраһим

3) Тормыш мәшәкате, нәрсә турында булса да кайгырту. *Район халкы бу шаушулы каршылауга мәҗбүри бер чара итеп карады, искитмәле һични булмагандай, шундук таралышып, һәркем үзенең көндәлек шөгыленә кереште.* С.Сабиров. *Картлар, балалар һәм хатын-*

*кызлар өсте ябулы көймәле арба тирәсендә көндәлек тормыш, көнкүреш шөгыльләре белән мәшгуль.* Р.Фәхретдинов

**ШӨГЫЛЬЛӘНҮ** *ф.* Берәр эш белән мәшгуль булу, эш башкару. *Лаборатория башаклы үсемлекләрне селекцияләү белән шөгыльләнә иде.* Х.Камалов. *Закир, бик мөһим эш белән шөгыльләнгән сыман, өстәл җәймәсендәге ипи валчыкларын сыпыргалады ---.* А.Әхмәтгалиева

**Шөгыльләнә башлау** Шөгыльләнергә totыну. *Рафаил абыйның киңәшен тотып, булдыра алган кадәр спорт белән шөгыльләнә башладым.* Ф.Яруллин. *1902 елда ул, энесе Гали белән бергәләп, китап сәүдәсе белән шөгыльләнә башлый.* А.Тимергалин

**Шөгыльләнә тору** Башка эш-гамәл башланганчы шөгыльләнү; һаман шөгыльләнү. *Ул текстларны төзәткәндә, текстолог текстлар туплау, искәрмә һәм аңлатмалар буенча материаллар җыю белән шөгыльләнә тора.* Мәдәни җомга

**Шөгыльләнеп алу** Тиз генә, кыска вакыт арасында шөгыльләнү. *Аннары ул берникадәр вакыт тыңлаучыларны гипнозлау белән шөгыльләнеп ала.* Ж.Юныс. *Аз гына арифметика белән шөгыльләнеп алыйк.* Казан утлары

**Шөгыльләнеп карау** Сынау өчен шөгыльләнү. *Йосыф игенчелек белән шөгыльләнеп караган.* В.Имамов. *Симаков 14 яшьлек чагында ике-өч ай бокс белән шөгыльләнеп караган иде.* Р.Сәгъди

**Шөгыльләнеп килү** Күптәннән, элек-электән, эзлекле рәвештә шөгыльләнү. *Үзегезгә мәгълүм: мин бөтен гомерем буена бакчачылык, умартачылык белән шөгыльләнеп килдем.* Т.Гыйззәт. *Ул Кол Гали әсәре белән инде берничә дистә ел шөгыльләнеп килә.* Х.Миңнегулов

**Шөгыльләнеп тору** Даими, һәрвакыт шөгыльләнү; әле, хәзерге вакытта, сөйләү моментында шөгыльләнү. *«Импульс» студентлар отряды хәйрия эшләре белән даими шөгыльләнеп тора.* Сәхнә. *Уен коралларында да һәрвакыт шөгыльләнеп торасың.* Шәһри Казан

**ШӨГЫЛЬЛЕ** *с.* Шөгыле, эше булган. *Хисамеддин, Гайса, Әбүзәр, Мохтар – төрле шөгыльле һәм табигатьле кешеләр.* Х.Миңнегулов. *Ә чегән карчыгының «денле итәрсез» диюен мин, мәсәлән, белемле, һөнәрле, шөгыльле итегез дип аңладым.* Р.Юсупова

**ШӨГЪБӘ** *и. гар. иск.* Бүлек, бүлекчә. *«Әльислах» оешмасының урыннардагы шөгъбәләрен, ягъни бүлекләрен булдыру буенча эш алып барыла.* И.Нуруллин

**ШӨ́ЙЛӘ** *рәв. диал.* 1) Шулай, шул рәвешле. *Сәңа шөйлә күңел баглар, күздин чишмәләр чаглар.* Г.Кандалый. *Балаларына да Җиһанша хәзрәт ни эшләргә боерса, шөйлә эшләделәр.* З.Һади

2) Һәрвакыт, гел. – *Бабай, – диде ул, – менә сиңа яңа сауган сөт керттем, эчеп ал, шифасы булсын. – Рәхмәт, кызым, син шөйлә мине шулай иркәлисең ---! – диде карт, онытын сөеп.* Т.Нәбиуллин

**ШӨКӘТ** *и.* Кыяфәт, килбәт, тышкы күренеш; ямь

**ШӨКӘТСЕЗ** *с.* **1.** 1) Ямьсез, шыксыз. *Чемоданнарының авырлыгын да тоймыйча, Дамир тышка атылды. Кинәт кенә баягы күркәм, таныш та, күңеленә якын да кала шөкәтсезгә әйләнде.* С.Шәрипов. *Стенаның буш калган урыннарында эленгән шәрә кызлар, әллә нинди шөкәтсез күренешләр төшерелгән фоторәсемнәр өчен исә кызга Гайшә апа алдында уңайсыз иде.* З.Хөснияр

2) Котсыз, килбәтсез, кыяфәтсез (кеше тур.). *Менә шушы үтә шөкәтсез бәндә авылның иң чибәр кызына гыйшык тота.* К.Тинчурин. *Мондый да шөкәтсез татарны беренче тапкыр күргән сыман, чуаш һәм урыс халкыннан торган кавем авызларын ачкан хәлләрендә болдырга текәлеп тын калды.* Ф.Яхин

**2.** *рәв. мәгъ.* Ямьсез итеп, килбәтсез рәвештә. *Базаның йортлары күп, ләкин берсенең генә тәрәзәләре якты, калганнары шөкәтсез караеп тора.* Н.Әхмәдиев. *Кыска туны изүенә озынча ияген тартып яшерде, аннары, башын чөеп, ияген алга чыгарып, тагын шөкәтсез салындырды.* М.Хуҗин

**3.** *и. мәгъ.* Ямьсез, шыксыз нәрсә яки кеше. *[Сабира (курчакны алып)]: Тагын бу шөкәтсезне түргә куйган.* А.Гыйләҗев. *Әбәу, күзе шөкәтсезнең, дәрте ташыган ата хамелеоннныкы кебек кып-кызыл.* Р.Кәрами

**ШӨКӘТСЕЗЛӘТҮ** *ф.* Шөкәтсез итеп күрсәтү. *Заркан, тилемсә кыяфәтен тагы да шөкәтсезләтеп, илчеләр утырган якка бара.* З.Хәким

**ШӨКӘТСЕЗЛӘ́Ү** *ф. к.* **шөкәтсезләтү**. *Ә иске, каралып черегән шифер түбә, кала-авылларны шөкәтсезли, --- гүзәл Кырым җиренең котын качыра.* Р.Зарипов. *Катырак җил иссә дә сыначак бит сабагы. Тирә-ягыбызны шөкәтсезләп тормаса шунда.* Н.Сәйяр

**ШӨКӘТСЕЗЛЕК** *и.* Ямьсезлек, шыксызлык, шөкәтсез булу сыйфаты. *Авызының кыеклыгы, иреннәренең калынлыгы аның шөкәтсезлеген тагын да көчәйтә сыман.* Н.Фәттах. *Ә Җабир, үзенең шөкәтсезлеген онытып, Әлинәгә ташлана.* Ф.Яхин

**ШӨКЕР** *и. гар.* **1.** Биргән нигъмәтләре өчен Аллаһка, аның тәкъдиренә карата кичерелгән канәгатьлек; гомумән шундый хисне, миннәтне тел белән әйтү. *Безгә җитә кулда булганы да, Кемдер өчен дөнья һаман тар. Житми, җитми, ай-һай, җитмәс икән, Мин дә шөкер димим әлегә. Егасым бар әле көчлерәкне, Ташлыйсым бар хаклык гүренә.* В.Фатыйхов

**2.** *кер. сүз функ.* Булганына канәгать, риза. *Шөкер, иң беренче бүләк ителгән автографлы китабым табылды.* Ф.Яруллин. *Газета-журнал битләре, шөкер, чиста килеш, буш килеш чыкмый.* Р.Миңнуллин

**3.** *хәб. функ.* Канәгать, риза. – *Сүз ирегә милициягә дә килеп җитәр әле ул, – диде Сакманов, күпмәгънәле итеп елмаеп. – Эштә, гаиләдә иминлектер бит? – Шөкер, – диде Гаяров иренеп кенә ---.* Т.Галиуллин. *Мине аяксыз калдырып та, җанымны матур килеш, йөземне ачык килеш саклаганың өчен шөкер!* А.Мансуров

**ШӨКЕ́Р ИТҮ** *ф.* Булганына канәгать булу, риза булу; артыгын таләп итмәү. *Барына шөкер итеп, югына зарланмый гына сабыр итеп яшәдек.* Г.Галиева. *Ярый әле, бәхеттән, мичкә гайкасы нык борылган булып чыкты, керосиныбыз түгелмәде. Шунысына шөкер итеп, --- арбаны кире урынына утырттык.* Г.Галиев

**ШӨКЕ́Р КЫЛУ** *ф. к.* **шөкер итү**. *Авыл халкы үз көнен үзе күреп, мал тотып, бакча үстереп, булганына шөкер кылып яши.* Г.Шәйхи. *Мин дә, бөтен сәламәт кешеләр сыман, көн туган саен, Аллага шөкер кылып, дога укыйукый, эшкә ашыгам.* М.Әхмәтшина

**ШӨКЕРЛЕ** *с.* 1) Шөкер итү гадәте булган, рәхмәтле. *Тәүфикълы да булу кирәк, шөкерле дә... Моннан язгач, аннан нишләрсез?! Тәүфикъсызга кәнфит тоттырмаслар, Шөкерсезләр калыр шикәрсез.* Р.Сәлахов

2) Шөкер итү хисе, канәгатьлек хисе белдергән

**ШӨКЕРЛЕК** *и.* Канәгатьлек хисе, шөкер итү хисе. *Булганына шөкер, биргәненә! Шөкерлектә – затың барлыгы!* Ф.Яхин. *Мактанудан түгел, шөкерлектән Бүгенге бу дөньям түгәрәк.* Ф.Дәү-

ләтгәрәева. *Барына шөкерлеге, кешеләргә авыр сүз әйтә белмәве, ярдәмчеллеге, ире иртә дөнья куйгач балалары хакына яшәве өчен хөрмәт итәбез.* Байрак

**ШӨКРАНА** *и. гар.-фар. к.* **шөкер**. *Моңарчы гаилә тормышлары турында гел мактау, сөенеч, шөкрана сүзләре генә яудырып йөрүче Әлмиянең шул бер җөмләсе акыллы карчыкка һәммәсен аңлатты да бирде ---.* К.Тимбикова. *Шөкрана, капитаныбыз Трофим Григорьевич та, беренче көннәрдәге кебек, эч пошырып янымда тормый, хәзер ул миңа тулысынча ышана.* С.Сабиров. *Үзен әсир төшермәгәненә менә шул чакта ул язмышына кабат-кабат шөкрана укыды.* Н.Әхмәдиев

**ШӨКРАНА́ ИТҮ** *ф. к.* **шөкер итү**. *Минем бик әйбәт дусларым булды, бу җәһәттән шөкрана итә алам ---.* Ә.Еники. *Син исән бит әле, шунысына шөкрана итәргә кирәк.* Ф.Бәйрәмова

**ШӨКРАНА́ КЫЛУ** *ф. к.* **шөкер итү**. *Мин баскычка бүтәннәрдән алдарак менеп, Аллаһы Тәгаләнең җир өстенә яраткан барлык могҗизаларына шөкрана кылып, «Аятел көрси»не укыдым.* Ф.Яруллин. *Якын белешләре, иптәшләре, аның бу халәтенә бераз гаҗәпләнеп: «Башыңны имә, исән кайтуыңа сөен, бар сәламәтлегеңә шөкрана кыл!» – дип юатырга ашыктылар.* Н.Хәсәнов

**ШӨКРАНАСЫЗ** *с.* Шөкрана итми, барына канәгатьләнә белми торган; рәхмәтсез. *Шөкранасыз кешедән икмәктоз кадерен белгән эт яхшы.* Мәкаль. *Кешеләрнең явыз икәнлеген белә идем, бу кадәр үк шөкранасыз, рәхимсез булырлар дип уйламый идем...* А.Гыйләҗев

**ШӨКРАНАСЫЗЛЫК** *и.* Шөкранасыз булу. *Халыкта «гөбәдиягә арка кую» дигән сүз дә бар бит әле. Анысы бездә үзе бер яман эш – шөкранасызлык санала.* Н.Исәнбәт

**ШӨЛДЕР** *и.* 1) Терлекнең кайдалыгын белдереп тавыш бирү өчен муенына тагылган кечкенә металл кыңгырау. *Өммикамал апай зәңгәр сатиннан муенса тегеп биргәч, колынның муенына кечкенә генә шөлдер тагып җибәрдек.* Г.Бәширов. *Дугадагы кыңгырау, мичәүдәге атлар муенындагы шөлдерләр, өздереп уйнаган гармун, яшьләрнең дәртле җыр тавышы – барысы да ярты юлда өзелеп, тынып кала.* Р.Кәрами // Гомумән кечкенә кыңгырау. *– Тыныч кына утыруыгызны үтенәм, – диде судья, алдындагы шөлдерне чылтыратып куйды.* Л.Ихсанова

2) Бәрмә музыка коралына, биюче киеменә һ.б.ш.га тагыла, эче куыш цилиндр формасында эшләнгән, чыңлап тавыш бирә торган деталь. *Барабан кысасындагы аркылы тимергә шөлдерләр тагылган.* Н.Фәттах. *Шәһәр мәйданнарында маңгаена тәңкә төрткән, ялана-яклы җиткән кызлар шөлдерләр селкеп биилләр, җырлыйлар – бөтен җирдә чисталык, нур, сөешү, җыр.* М.Мәһдиев

**ШӨЛДЕРӘТҮ** *ф. йөкл. юн. к.* **шөлдерәү**. *Таң җиле тәрәзә алдындагы усак яфракларын шөлдерәтергә тотынды. Алар мондый вакытта аеруча калтыранып, бик моңлы шөлдериләр.* А.Шамов

**ШӨЛДЕРӘ́Ү** *ф.* Шөлдер-шөлдер килү, шөлдер-шөлдер иткән тавыш чыгару. *Күпмедер секундтан соң ул аңына килде, аның әйләнә-тирәсендә кипкән кәлшәләре белән көзге җилдә шөлдерәгән саргылт сабаклы чүп үлән иде ---.* М.Мәһдиев

**Шөлдерәп кую** Бер тапкыр шөлдерәгән тавыш чыгару. *Шөлдернең шөлдерәп куйганы ишетелде*

**Шөлдерәп тору** Өзлексез яки әледәнәле шөлдерәү; әле, хәзер шөлдерәү

**ШӨЛДЕРЕК** *и. к.* **шөлдер** (*1 мәгъ.*). *Урамга чыккач, ишан хәзрәтләрен көмеш иярле, көмеш йөгәнле, муенына алтын шөлдерек таккан кечкенә ишәк өстенә күтәреп атландыралар.* Ә.Еники

**ШӨЛДЕРЛЕ** *с.* Шөлдере булган; шөлдер тагылган. *Шөлдерле гармунын уйнап, йөрәгемне җилкетә.* Җыр. *Унөч яшьлек Нуретдин исемле малай кулына шөлдерле барабан тоткан да яшь аюны биетә.* М.Мәһдиев. *Җиз кыңгыраулы, көмеш шөлдерле атлар күз явын алырлык итеп бизәлгәннәр.* Ф.Хатипов

**ШӨЛДЕ́Р-ШӨЛДЕР** *иярт.* Вак металл әйберләр бер-беренә бәрелүдән бертуктаусыз яки әледән-әле, ритмик рәвештә чыгып торган тонык кына яңгыраулы тавышны белдерә. *Челдер-челдер... Шөлдер-шөлдер... Еракта ат тавышымы?* Ф.Яхин

**ШӨЛДЕ́Р-ШӨЛДЕР ИТҮ** *ф.* Шөлдер-шөлдер кебек тавыш чыгару. *Әкрен генә иртәнге салкын җил исеп куйды, усак яфраклары шөлдер-шөлдер итә башладылар.* Г.Әпсәләмов

**ШӨЛДЕ́Р-ШӨЛДЕР КИЛҮ** *ф. к.* **шөлдер-шөлдер итү**. *Ишек урынында шөлдер-шөлдер килеп ачыла торган бамбук чаршау.* Т.Әйди. *Әйе, ул заманда кайсы якка карап сәфәр чыксаң да, шөлдер-шөлдер килеп шөлдер каккан дугалы җиңел арба – тарантаслар кирәк була.* Л.Хәмидуллин

**ШӨЛДИ́ КОШСЫМАННАР** *и. зоол. күпл.* Дөньяда киң таралган, суда һәм су янында яши торган кошлар отряды; *русчасы:* **ржанкообразные**

**ШӨЛДИ** *и. зоол.* Шөлди кошсыманнар отрядының берничә семьялыгына караган, су буйларында яши торган төрле зурлыктагы һәм авырлыктагы кошларның гомуми атамасы; *русчасы:* **кулик**. *Шөлди үзенең озын томшыгын сазлавыкка батыра да бераз тыңланып тора, аннары тиз арада җир астыннан симез-симез кортлар сөйрәп чыгара.* Җ.Тәрҗеманов. *Җәйге күлдә гел бер күренеш: камышлар арасында шөлди дигән сөйкемсез кошчык йөзсә, су өстендә буш көймә чайкала. Шөлди булып шөлди күлен, үз оясын тапкан.* К.Латыйп

**ШӨЛЛӘ́Ү** *ф. диал. к.* **шүрләү** I. *Бары тик полк командирыннан гына бераз шөлли һәм аны хөрмәт итә.* М.Вәлиев. *Мин эре мөгезле хайваннардан шөллим.* Н.Гыйматдинова

**Шөлләп йөрү** *к.* **шүрләп йөрү**. *Ләкин Үргәнечтәге төп сараена кайтып гомер сөрүдән, Терекүн зәхмәтле сихере астына эләгүдән һаман шөлләп йөри.* В.Имамов

**Шөлләп калу** *к.* **шүрләп калу**. *– Башкаларда минем эшем юк. Минем үз хәлем хәл. Әгәр чарыксыз җибәрсәгез, үпкәләштән булмасын! – дидем, директорның шөлләп калуын күргәч батыраеп китеп.* В.Нуруллин. *Нәгыймь моның каршында күкрәк киерсә дә шөлләп калган иде.* К.Кара

**Шөлләп кую** *к.* **шүрләп кую**. *Ленар, Әмирдәге кискен үзгәрешне күреп, сизеп, бу бәндә миңа сугып җибәрә күрмәсен дип шөлләп куйды.* Т.Галиуллин. *Директорның дәрескә керүе Мәрзияне каушатып җибәрде. «Завучы булса бер хәл иде, баштук нигә үзе керә икән?» – дип шөлләп куйды.* Ә.Моталлапов

**Шөлләп тору** *к.* **шүрләп тору**. *Кайтканда, әнисе белән сөйләшергә шөлләбрәк тора иде, мунчадан соң хәл дә, кыюлык та керде.* Р.Хәбибуллина. *Шунлыктан прораб-мастерлар алдында ялагайлануны белмәгән техника куркынычсызлыгы инженерыннан барысы да шөлләп торалар.* Р.Кәрами

**Шөлли башлау** *к.* **шүрли башлау**. *Бу ачышым үземә дә кәмит булып китте: уята алмам дип шөлли дә башладым.* Н.Хәсәнов. *Сержант җилкәсен кашып алды. Аллага шөкер. Шөлли*

*башлау дигән сүз иде бу. Миңа нәкъ шул кирәк иде. Курку һәм куркыту – Рәсәйнең идарә итү ысулы...* М.Юныс

**Шөлли калу** *к.* **шүрли калу**. *Хатынның сүзне чынга алуыннан, уеннан уймак чыгу ихтималыннан бераз шөлли калган кибетче, артка чигенеп, бәхәсчеләрне тынычландырырга ашыга.* Т.Галиуллин

**Шөлли төшү** *к.* **шүрли төшү**. *[Рөстәм:] Малайлар, әллә бу чынлап та тылсымлы китап микән? Мин дә шөлли төштем, күңелдә ниндидер шом бар.* А.Гадел

**ШӨЛЛӘ́Ү** *и. диал. к.* **шүрләү** II. *Кот очу, курку, шөлләү кебек хисләр юк иде күңелендә.* Т.Галиуллин. *Рәсим --- сәрви куагы арасында күренер-күренмәс торган кеше шәүләсен чамалады. --- Бер мизгелгә шөлләү тойгысы кичерсә дә, куркудан тиз арынды.* Ә.Моталлапов

**ШӨМРӘЮ** *ф. сир. к.* **шомраю**. *Әниләре, --- бүреләргә шөмерәеп караган ябык атны хәтерләтеп, арткарак чигенеп куйды.* Ә.Баян

**ШӨПШӘ** *и.* **1.** Элпәканатлылар отрядыннан берничә семьялыкка караган, элпә канатлы, аркылыга чиратлашып килгән кара һәм сары төстәге юллары булган, бал кортыннан эрерәк чага торган бөҗәкләрнең гомуми атамасы; сагызак; *русчасы*: **оса**. *Ә беркөнне урманда шөпшә оясын таптым. Кәрәзендә бал иде.* Ф.Яруллин. *Көн кыздыра башлагач, киндер басуы өстенә шөпшә, төклетура, күбәләк, бал кортлары җыелырлар, туй итәрләр инде.* В.Имамов

**2.** *с. мәгъ.* Нечкә, нәзек. *--- әле кызыл, әле зәңгәр, әле яшел телефоның чылтырый, әле ишектән шөпшә билле секретарша кереп, кәгазь калдырып чыгып китә ---.* М.Мәһдиев. *Әнә бит ул, кул сузымы арада гына Гөлмәрьям. Шул ук шөпшә билле, ялан тәпиле кызыкай.* Ф.Садриев

◊ **Шөпшә оясына таяк тыгу** 1) Тынычлыкны бозу, тузгыту, тәртипсезлек урнаштыру, ыгы-зыгы китерү. *Хәйдәр Әлим дигән бер зыялы вөҗдан иясе бу хакыйкатьне читләтебрәк булса да әйтеп биргән иде. Шөпшә оясына таяк тыгып айкаган шикелле булды ул. Дәрәҗәле тәнкыйтьчеләр, дәррәү күтәрелеп, Хәйдәр Әлим өстенә ябырылдылар ---.* А.Тимергалин. *--- гайрәтле нотык сөйләде, яу эшләрен, Иван гаскәрләренең торышы турында төгәл, кыю боерыклар биреп, шөпшә оясына таяк тыккандай, өметсез йокымсыраган угланнарны, бәкләр, мирзаларны тузгытты.* Р.Батулла; 2) Коткы салу, болгату

**ШӨПШӘ́АШАР** *и. зоол.* Карчыгага кошлар семьялыгыннан күбесенчә шөпшә, төклетура, бал кортлары личинкалары белән туклана торган ерткыч кош; шөпшә кошы; *русчасы:* **осоед**

**ШӨПШӘ́ КОШЫ** *и. зоол. к.* **шөпшәашар**

**ШӨР** *и. иск. к.* **шыр** III. *Әмма беркөнне икесенең дә сулышы кысылып, эченә шөр йөгерде. – Һашия райунга җыена, духтырга, юллык акча бир, ди.* Н.Гыйматдинова

◊ **Шөр җибәрү** *к.* **шыр җибәрү**. *– Иван казанлыларга әйткән, хан белән ханбикәне үз теләгегез белән тотып бирмәсәгез, дәүләтегезне юк итәм, дигән. – Шөр җибәргән инде тегеләр, шулаймы?* М.Әмирханов

**ШӨРЕП** *и. нем.* 1) Агач, металл әйберләрне беркетү өчен спираль сырлы кадак; винт. *Ул ниндидер бармак башыдай чүкечләр белән шакы-шокы килеп, безләр, эскәкләр белән, сырлы тәгәрмәчләр, шөрепләр белән булаша.* Н.Фәттах. *Шунда гына без сәгать эченә ике шөреп белән беркетелгән яңа җиз түгәрәккә игътибар иттек.* А.Тимергалин

2) *күч.* Нинди дә булса эштә кечкенә роль уйнаучы, ниндидер вакыйга барышында сизелерлек йогынты ясарга сәләтсез кеше. *Без сине депутат иттек, дип кабатлап торгач, бу кеше инде ирексездән үзен партия лидерларына бурычлы итеп саный башлый. Гаять тыңлаучан бер шөрепкә әверелә. Команда системасының шөребенә әйләнә.* М.Вәлиев. *Тормышыңның күңелсез бертөрлелегеннән зарланырга, үзеңне кемнеңдер кулындагы вак бер шөреп итеп тоярга хакың юк.* М.Кәбиров. *Дәүләт машинасы минем бер шөреп сыйфатын алырга тиешлегемне яхшы төшенеп эш иткән, һәм мин нәкъ шул шөреп булып яшәдем дә инде.* Гасырлар авазы

3) *күч. гади с.* Фикерләү сәләте, акыл; ми. *Бу кадәр миңгерәү булырга ярамый бит инде. Азрак башыгыздагы шөрепләрне эшләтергә кирәк.* Аманулла. *Зиһен шөрепләре тиешенчә эшли белми икән, йөрсен татар, кулына чүкеч тотып, я урам себереп.* В.Имамов

◊ **Шөребе бушау** 1) Акылына зәгыйфьлек килү, аңгыралану, иләсмиләсләнү, миңгерәүләнү. *Син әллә ычкына башладыңмы, тилебаш, шөрепләрең бушаганмы, дип кычкырды Кәрнәй, ачуланып.* Х.Камалов. *Укыта-укыта, шөрепләрең бушады мәллә, Васька?* Н.Гыйматдинова; 2) Гәүдәсен тота алмау, буыннар йомшару. *– Әй син, шөребең бушаган, юкка мәшәкатьләнмә! – дигән сүзгә [исерекнең] намусы килде бугай, ул тагын биергә тырышып карады, тагын булдыра алмый, бер якка ауды.* М.Гафури; 3) Көчен, тотрыклылыгын югалту. **Шөребе какшау** *к.* **шөребе бушау**. *[Гәрәйша:] Сез колхозникны адәм мәсхәрәсе итмәкче буласызмы, җәмият? Корсакның шөрепләре какшаган. Оятлы итәрсез.* А.Алиш. *Фәкать шуны гына беләсе иде: мондый һөҗүмнәрдән социализм фикеренең ничә шөребе какшады икән?!* Ф.Әмирхан. **Шөребе күгәрү** Уйлау, фикерләү сәләте киму, начарлану. *Шөрепләрең күгәрде мәллә?!* Н.Гыйматдинова. **Шөребе тутыгу** *к.* **шөребе күгәрү**. *Шундый шартлар эченә куйганнар икән безне, минме аңа гаепле? Шартларны бит мин тудырмыйм. Башың әзрәк эшлиме, әллә шөребе тутыкканмы?* Х.Камалов. **Шөребе ычкыну** *к.* **шөребе бушау**. *Күбрәк уйласаң, шөрепләрең ычкына башлаганны сизми дә калырсың.* Н.Әхмәдиев. *Ниһаять, башларындагы кайбер шөрепләре ычкынып китеп, шәрә килеш Минзәлә урамына чыгып йөгергәннәр.* Ф.Баттал. **Шөрепләрен бору** 1) Мәсьәләне яки фикерне берәр якка юнәлтү. *Ничек шөрепләрен боргалагандыр, берзаман чибәр егет Гөл апаның үгетләренә күнә.* Н.Гыйматдинова; 2) Буйсындыру, карату. *Салисә өйдә чакта шөрепләрен нык кына борып тота иде, хәзер тәмам чыгырдан чыктылар.* Сөембикә

**ШӨРЕПЛӘ́Ү** *ф.* Шөреп борып беркетеп кую, шөреп белән ныгыту. *Өстәл аякларын шөрепләү*

**Шөрепләп бетерү** Барысын да, ахырга кадәр шөрепләү. *Әзер детальләрне шөрепләп бетерү*

**Шөрепләп кую** Алдан ук шөрепләү, шөрепләнгән хәлгә китереп калдыру. *Насос көпшәсенең тишелгән төшенә тимер атлама кигертеп, шөрепләп тә куйды.* Х.Камалов

**Шөрепләп чыгу** Һәрберсен берәмберәм шөрепләү

**ШӨРИ** *и. гади с.* Курку, өркү хисе, шик-шөбһә. *Бу шигемә үземнең үк ышанасым килмәсә дә, эчтә шөриләр тыпырчына башларга бу бик җитә калды.* Р.Төхфәтуллин

**ШӨРЧЕК** *и. рус диал.* Турыканатлылар отрядының чын чикерткәләр семьялыгыннан ата төрләре канат өсләкләрен бер-берсенә ышкып ч螺ерелдәгән тавыш чыгара, ягылган җылы бүлмәдә яши торган соры төстәге бөҗәк; өй чикерткәсе; *русчасы:* **сверчок**

**ШӨҺРӘТ** *и. гар.* Кемнең яки нәрсәнең дә булса яхшы яклары, аны башкалардан аерып торган, өстен итеп күрсәткән уңай сыйфатлары турында киң таралган сүз; дан, танылганлык, атаклылык. *Урыс нәшриятларында китап чыгару, аның гәзит-журналларында басылу урыс язучысы өчен дә авыр чакта мондый шөһрәткә ирешер өчен, татар-башкорт язучыларына, урысларга караганда, ун-йөз мәртәбә артыграк тырышырга кирәк иде.* К.Тимбикова. *Тыйнак кына, салмак сүзле, кыенсынып кына: – Илһам Шакиров безнең институт студентлары белән очрашуга килмәсме икән? – диде. Илһамның ул еллардагы шөһрәтен, аның әүлиядай бер шәхес икәнен аңлаган кешегә бу теләк хәтта тормышка ашмастай ерак кебек тоелыр иде.* Р.Батулла

◊ **Шөһрәт алу** Кемнең дә булса мактаулы исеме таралу, танылу, дан алу, дан казану, данга, мәртәбәгә, дәрәҗәгә ирешү. *Үзенең коммунистик принциплардан чигенмәсен белдереп шөһрәт алган Ленинград химигы Нина Андреева да «үзгәртеп коруны оештыручылар» дип Рональд Рейган белән Маргарет Тетчерны исәпли икән.* А.Гыйләҗев. *Беренче укытучы... Әнә Чыңгыз Айтматовка шул исемдәге әсәре дөньякүләм шөһрәт алып килде.* Т.Галиуллин. **Шөһрәт казану** *к.* **шөһрәт алу**. *Ул бит – Англиянең элекке премьер-министры, заманында зур дан, шөһрәт казанган кеше.* А.Хәсәнов. *Төп сезнең авылдан чыгып, --- татар дөньясында нинди дә булса бер юлда дан тоткан, шөһрәт казанган, исем чыгарган кешеләр бармы?* Гали Рәхим. **Шөһрәт табу** *к.* **шөһрәт алу**. *Хәзерге көндә дә алардан обсерватория мөдирләре, фән мөгаллимәләре яки астрономнар, география белән геология фәнендә зур китаплар авторлары, --- гыйльми җәмгыятьләрдә әгъзалар, вә һәрбер фәндә шөһрәт тапкан хатыннар бетәсе түгел.* Г.Буби

**ШӨҺРӘТЛЕ** *с.* Шөһрәте, даны киң таралган; нәрсә белән дә булса танылган; күренекле, атаклы. *Дөньяны куллрында тоткан, тормышның тәртибен саклаган иң көчле, шөһрәтле кешеләрнең берсе шушы сүзләрне теле барып ничек әйтә ала!* Ә.Баян. *Мальорка утравын бөтен җир шарындагы шөһрәтле курорт дип йөртәләр.* М.Мәһдиев

**ШӨҺРӘТПӘРӘСТ** *с. гар. иск. кит.* Шөһрәт, дан, дәрәҗә, мәртәбә сөючe. *[Фәсхи:] Мине туймас шөһрәтпәрәст кеше итеп күрсәтмәгез.* Ф.Сәйфи-Казанлы

**ШӨШ** *и. к.* **шеш** II (*1 мәгъ.*). *[Үгез] колхоз ындырына кереп, колхозның әвен базы өстенә корылган шөшкә ышкынып, кашынырга тотынды.* Ф.Хөсни

**ШӨШКЕЛӘ́Ү** *ф. диал.* 1) Нинди дә булса җәнлек яки җанварны оясыннан төрткәләп, гөҗгеләп куып чыгару. *Кайры белән агач кәүсә арасына шул озын агач пычакны тыгып шөшкели ---.* Ш.Маннур. *Мәкчим озын колгасы белән өнгә төрткәли, хәтта ярсып-ярсып шөшкели иде. Менә өннән авыр мышнаган тавыш, ризасызлык авазлары ишетелде.* Р.Сибат

2) *куч.* Гел әрләп, тиргәп тору, төрткәләп торып теңкәсенә тию. *Хәсән өйдә юкта аның хатыны Зәйтүнәнең күзен дә ачырмый иде, аны гел шөшкеләп, өтәләп кенә тора, юк-бар нәрсә табып, Хәкимә карчыкка әләкли иде.* Ш.Еникеев

3) *куч.* Көчле һөҗүм ясау, җиңелүгә дучар итү, дөмбәсләү, куып чыгару. *Кышкы һөҗүмнәр вакытында фронт гаскәрләре немецны көзен килеп чумган оясыннан шөшкеләп чыгардылар.* Ш.Маннур

**Шөшкеләп тору** Еш, әледән-әле шөшкеләү

**ШӨШЛӘ́Ү** *ф.* 1) Шөш белән беркетү. *Әвенне шөшләү*

2) Шөшкә кидерү; шөшкә кидереп кыздыру. *Ялкынга тотып бөтен килеш кыр кәҗәләрен шөшләп, безне сыйларга ит әзерлиләр.* М.Әмир

**ШӨШЛЕ** *и. мар.* Чабата үргәндә кулланыла торган бераз кәкрерәк, калын без кебек корал; сыяу. *Хәкимҗаңның бабасы пеләш Миңлебай, шөшлесе белән шак та шок суккалап, түр яклрында чабата ясап утыра.* Г.Бәширов. *Бабайдан калган мирас та бик зур түгел – ике иске чабата белән бер кәкре шөшле генә.* Р.Вәлиев

**ШПА́ГА** *и. ит.* Өч, дүрт яки алты кырлы, нәзек озын һәм туры йөзле салкын корал. *Киң кунычлы, биек үкчәле итекләр, башларына киң кырлы эшләпәләр кигән мушкетёрлар кулларына шпагалар, кылычлар тоткан.* Р.Батулла. *Һәм ул тыелгысыз ярсу төстә шпагасы белән алабуталарны уңлысуллы туракларга кереште. Ул селтәнгәндә, корыч чыбыкның чажлавы музыканы да басып китә иде.* Ә.Гаффар

**ШПАГАТ** *и. нем.* 1) Киндер сүсе яки җитен җебен ишеп яки бөтереп эшләнгән нечкә нык бау. *Беркөнне хәтта шул матчага бармак юанлыгы ыргак та кагып куйдым, элмәккә дип юан шпагат юнәттем.* Ф.Баттал // Гомумән, хуҗалыкта кулланыла торган нечкә нык бау. *Өзелүне, черүне белми торган, «буровой җебе» дип даны чыккан капрон шпагаттан үрелгән садокта балыкның да җаның ниндиен тели – шунысы тотып куелган иде ---.* М.Хәсәнов

2) *спорт.* Гимнастика һәм акробатикада аякларның берсен алга, икенчесен артка яки як-якка туры сызык буенча куеп утырудан гыйбарәт фигура. *Менә дигән җыр! Аны җырлар өчен, мостик түшәсе дә юк, шпагатка утырырга да кирәкми. Болай да йөрәккә үтеп керә ул.* Аманулла. *Мәктәптә гимнастика белән дә шөгыльләндем бит әле мин. Шпагатлар ясыйм.* Д.Нуруллина

**ШПАКЛЁВКА** *и. рус* 1) Буяласы урынның тишек-ярыкларын каплау, тигезсез урыннарын тигезләү, сылау өчен әзерләнгән пастасыман яки порошоктан ясалган махсус материал. *Юылган стена кипкәч, барлык ярыкларны куе шпаклёвка белән сылыйлар.* Өегез ямьле булсын

2) Шундый материал белән сылау, тигезләү эше. *Алсуны бүген шпаклёвкага куйдылар*

**ШПАКЛЁВКАЛАУ** *ф.* Шпаклёвка эшен башкару, тишек-ярыкларны махсус измә белән сылап тигезләү

**Шпаклёвкалап бетерү** Шпаклёвкалау эшен тәмамлау

**Шпаклёвкалап чыгу** Башыннан ахырына кадәр шпаклёвкалау

**Шпаклёвкалый башлау** Шпаклёвкаларга тотыну

**ШПАЛ** *и. голл.* 1) Тимерьюл рельслары астына ныклык өчен аркылы салына торган агач яки тимер-бетон борыс. *Бу атнада тимерьюлга эшкә йөрдем. Шпаллар алыштырдык, чуерташ тараттык.* А.Гыйләҗев. *Яңавылны алгач, аклар станциядән бер-ике чакрым җирдә тимерьюл рельсларын һәм шпалларын сүтеп куйганнар икән.* В.Нуруллин

2) 1943 елга кадәр Совет Армиясенең югары команда составы кия торган форма якасындагы аерымлык билгесе. *--- фашист атмады. Ул Назимовның*

*якасындагы шпаллары белән күкрәгендәге орденын күрде булса кирәк.* Г.Әпсәләмов. *Ишек төбендә алмашлап утырган, гимнастёрка якаларындагы петлицаларга икешәр шпал таккан таныш түгел ике хәрби вагон ишегеν ачарга рөхсәт итми.* З.Зәйнуллин

**ШПАЛЕР** *и. нем.* 1) Төрле бизәкләр, сурәтләр төшереп кулдан тукылган стена келәме, гобелен

2) Тукылган обой. *Шпалер сатып алу*

3) *сөйл.* Обой

4) Үрмәләп үсә торган үсемлекләр өчен колгага бау яки чыбык тартып эшләнгән махсус киртә, рәшәткә. *Бөрлегәнне өскә тарттырып, казыклар кагып, шпалерларга бәйләп кую кирәк.* Сөембикә. *Кыярның үрмәле сабакларын баудан (шпалердан) сүтеп алыгыз һәм сабакның аскы өлешен, бөҗралап, туфракка урнаштырыгыз.* Кызыл таң

**ШПАНА** *и. рус гади с.* 1) Бозык юлга кергән кеше, вак карак, жулик. *Элеккеге елларда --- пассажирский поездларның баскычларына асылынып, --- шпаналардан таланып --- йөргән көннәремне исемә төшердем ---.* М.Мәһдиев. *Шпаналарга җитә калды: тиз генә мәкер кордылар, бер егет мотоциклдагы сумкасыннан кайчы алып килде.* С.Шәрипов

2) Шундый кешеләр. – *Урам шпанасы бәйләнгән генә җитмәгән. Инде кредиторлар борчый башлады, – дип, кыяфәтенә борчулы, уйчан төсмер бирергә тырышып башлады сүзен Хәлил.* Т.Галиуллин. *Болар – шәһәр шпанасы, боларның ни иманы, ни йөзе юк, алар, күселәр кебек, төркем-төркем йөри.* Г.Хәеров

**ШПАНАЛЫК** *и.* Шпана булу. *Ул шпаналык тормышы турында әрнеп, чын күңеленнән борчылып, аларны харап булган еллар итеп сөйли иде.* А.Шамов. *Төрлесен күргән, үзе әйткәнчә, Казанда шпаналыкта да йөргән, әмма дөрес уйга килеп укырга кергән.* Татарстан яшьләре

**ШПАНГО́УТ** *и. голл. диңгез., авиа.* Самолёт, дирижабль яки судно корпусына ныклык бирү өчен куелган аркылы агач яки металл борыс. *Көймәгә унбиш шпангоут, гадирәк итеп әйткәндә, кабырга кирәк иде. Көймәнең төбе һәм бортлары шул кабыргаларга кадаклап куела. Шпангоутлар өчен рейкаларны калын такталардан ярдылар.* А.Тимергалин

**ШПАРГА́ЛКА** *и. пол. сөйл.* Имтиханда яисә язма контроль эшләр вакытында үз белемнәренә ышанмаган укучының яшереп файдалану өчен сорауларга җавапны алдан әзерләгән яки формулалар һ.б. язылган кәгазе. *Орден таккан, егерме-егерме ике яшьләрдәге бу хатын кызарып, өметсезләнеп утыра иде – шпаргалканы алгач, озын керфекләрен күтәреп Рушадка карады, мөлаем карашы белән сүзсез генә аңа рәхмәт әйтте.* М.Мәһдиев. *Сәлим Хәйдәровичның «Имтиханнарга шпаргалкалар ясап маташмагыз. Барыбер карый алмаячаксыз» дигән сүзләре искә төшкәч, төн йокылары качты малайның.* Р.Галиуллин

2) Берәр нәрсә турындагы чыгышның алдан әзерләп куелган тексты. *Гобәйдулла хәзрәт чапан кесәләрен актара, шпаргалкаларын эзли. Әһә, тапты. Рәхим итегез, хәзрәт! Гобәйдулла тавышы. Кхм-кхм. Бисмилла диеп башладым лекциямнең башларын.* Г.Афзал

**ШПАТ** *и. нем.* 1) *минер.* Юка катламлы минералларның гомуми атамасы. --- *пыяла, аракы, шпат заводлары эшли башлады, фарфор өчен ак балчык, алебастр, нефть, кварц, күкерт чыгару җайга салынды.* Җ.Рәхимов

2) *махс.* Атларда сикерү буынының остеоартрозы

**ШПА́ТЕЛЬ** *и. нем.* 1) Төзү эшендә шпаклёвканы сылау яки тигезләү, иске замазка, буяуны кырып төшерү һәм обойны куптару өчен кулланыла торган, сыгылмалы юка корыч калак рәвешендәге эш коралы. *Ә анда эш көтә: кечкә хәтле беләкләре талганчы буяу-сылау белән мәш килерләр, чөнки һөнәрләре шул. Аларның кулларында тигезләгеч, шпатель, пумала кебек инструментлар уйнаклап торыр ---.* Р.Кәрами. *Хатын --- озын такта тигезләгечен куя-куя, дивар тигезлеген тикшерде. Аннары тагын тастагы измәне шпателе белән стенага тиз-тиз атып алды.* Ф.Җамалетдинова

2) Рәссамлык эшендә буяуны киндергә сылап тигезләү, грунтлау һ.б.ш. өчен кулланыла торган үтә юка һәм сыгылмалы пычак формасындагы калак. *Башта буяуны агач таякчык яки шпатель белән тукымадан кырып төшерегез, аннары тукыманың кире ягыннан үсемлек мае сөртеп, ярты сәгать тотыгыз.* Мәйдан

3) *мед.* Авыз эчен, тамак төбен караганда, хирургия операцияләре вакытында һ.б.ш.да кулланыла торган калаксыман инструмент. *Мотаһир шпательне стерилизацияләде дә шуның белән авыруның тешләренә төртептөртеп карады.* Р.Кәрами

**ШПИК** I *и. нем.* Дуңгызның тире астындагы маен тозлап ясаган ашамлык. *Емелькин, --- чүпрәккә төргән шпигын чыгарып, телем-телем кискәләп, бик тәмләп кенә ашарга тотынды.* Ә.Еники. *Тәмләп ашарга керешәбез дигәндә генә, алама-шалама киемле биш-алты кеше аларны урап алды. – Солдат, солдат, сатлык шпигың юкмы?* А.Гыйләҗев

**ШПИК** II *и. сөйл. пол. к.* **шымчы**. *Егеткә шик төште. «Бу жулик түгел. Моңа пальто кирәкми. Бу – шпик. Бу – филёр», – диде дә Булатларга керми үтеп китте.* Г.Ибраһимов. *Шпиклар аркасында безнең группа жандарм идарәсенә билгеле булды.* М.Мәһдиев

**ШПИКЛА́У** *ф.* 1) Итне кискәләп, эченә тыгызлап дуңгыз мае тутыру. *Киек итен шпиклау*

2) *күч.* Күпләп, тыгызлап тутыру, дыңгычлау. *Дошманнар аның бөтен гәүдәсен пулялар белән шпиклый*

3) *күч. ирон.* Нинди дә булса мәгълүмат, белем һ.б.ш.ны кирәгеннән артык бирү. *Яшь галим чыгышын буш сүзләр белән шпиклый*

**Шпиклап кую** Алдан ук яки тиз генә шпиклау

**ШПИЛЬ** *и. голл.* 1) Бина түбәсендә пирамида яки конус формасындагы очлаеп торган өскорма. *Аэровокзал түбәсендәге шпильгә тиеп үк күк йөзендә соры сыек болыт йөри.* М.Мәһдиев. *Мотаһир --- алда, чиркәү дисәң – тәбәнәк, часовнямы шунда, кыскасы, түбәсе манара сыманрак итеп очлаеп эшләнгән нindидер бина күрде. Очлы шпиле дә бар, хәтта икәү дә әле.* Р.Кәрами

2) *диңгез.* Судноларда якорь төшерү-күтәрү өчен яисә йөк төяү-бушату өчен хезмәт итә торган вертикаль чыгыр. *Команда тормышында тагын бер яңалык мин пароходка кайткан көнне булды. Шуның алдыннан гына без боцман Мәрфуга белән мин койрык якта яңа ремонтланган шпильне эштә сынап маташа идек.* С.Сабиров. *Тәҗрибәле бурлаклар шпильдә эшләүгә караганда лотта яки рейдда эшләүне артыграк күрәләр.* М.Гали

**ШПИ́ЛЬКА** *и. нем.* **1.** 1) *тех.* Детальләрне бер-беренә тоташтыру өчен металл кадак яки сырлы стержень. *[Васька] зур бер шпилька шикелле тимерне өстәлгә суга.* Г.Камал. *Миңа бүген дә, --- чәнти бармак кадәрле генә --- шпилька кайтып җитмәү аркасында,*

*баш конвейерыбыз сәгать буе диярлек туктап торды.* Р.Вәлиев

2) Чәчне кыстырып, кадап кую, җыеп тоту өчен ике япьле эләктергеч. *Тәрәзәм уртасыннанрак җирдә аунап яткан бер шпилька таптым: гади генә черепаха шпилька.* Гали Рәхим. *Чәчләремне җыйнап, шпилькалар белән кадап-кадап куйдым.* Ф.Садриев

3) Хатын-кыз туфлиенда очлы нәзек биек үкчә. --- *үкчәсендәге шпилькасы без кебек очлы туфли алып бирдем үзенә!* Ф.Баттал // Шундый үкчәле туфли. *Бу җәйдә биек, очлы үкчәле туфлилар, ягъни шпилькалар модага керде*

**2.** *с. мәгъ.* Очлы нәзек һәм биек (үкчә тур.). *Бакчага кереп, әни ял итәргә яраткан эскәмиягә утырдым. Монда да халык. Чуар кием, шпилька үкчәләр, челтәрле сандал, күннән үргән чабаталар.* М.Хәбибуллин. *Кыйммәтле юка колготкилар тарттырып куйган аякларына шпилька үкчәле, --- кара төстәге туфлиларын киеп --- мәктәпкә йөгерде.* Н.Көбәш

**ШПИНАТ** *и. нем. бот.* Амарантчалар семьялыгыннан озын сабаклы, тар яфраклары яшелчә итеп кулланыла торган бер яки икееллык үлән үсемлек. *Ашау-эчү ягы да бик читен иде. Көненә безгә 275 грамм --- ипи, --- бер литр баланда бирәләр. Баланда шпинат суы яки кишер, шалкан суыннан гыйбарәт.* М.Җәлил. *Ресторан-кафетерийларында шпинат белән флешьләренә (бака үләне белән бака ите) кадәр ашарга туры килде.* Г.Фәхретдинов

**ШПИНГАЛЕТ** *и. фр. махс.* 1) Тәрәзә яки ишектә зур булмаган шудырмалы металл бик. *Ә бит бик тырышса, Габделнур пәке очы белән өйалды ягыннан ишек тактасына аркылы беркетелгән шпингалетны да шудырып куя алган булыр иде.* Р.Кәрами. *Исмәгыйль --- тәрәзәнең шпингалетын да үзе теләгәнчә ясата.* Б.Урманче

2) *күч. шаярт.* Кыска буйлы яшүсмер, яшь егет. *– Ничәнче класста укый соң синең шпингалет? – диде ул, беркөнне Нәгыймгә югарыдан карап.* К.Кәримов. *– Кая кайтасың, – дип сорыйбыз без синнән, шпингалет? – Каенсарга! – диде Хәбир, «шпингалет»ның юньле сүз түгеллегенә җавап итеп.* Х.Бәдигый

**ШПИОН** *и. нем.* 1) Шпионаж белән шөгыльләнүче яшерен агент. *Финнарга әсир калган берәүне, төрле методлар кулланып «Мин фин шпионы» дип язган кәгазьгә кул куйдырганнар.* Х.Камалов. *– Син, фәләненңне фәлән итим, немец шпионы, теге сугышта да немецка хезмәт иткәнсең, – дип, картны бик гарьләде.* М.Мәһдиев

2) *сөйл.* Шымчы, җасус, яшерен полиция агенты. *Бу марҗа кызы шпиондыр, мине бүген сагалап, төнлә тотып алырга әзерләнәләр булыр, дигән шиккә төште.* Г.Ибраһимов. *Ике көн өйдән чыгарга куркып ятам. Һәр почмак саен күзәтүчеләр, шпионнар куйганнар ---.* Г.Каюмов

**ШПИОНАЖ** *и. фр.* Икенче бер дәүләткә, фирмага һ.б.га тапшыру нияте белән хәрби яки дәүләт сере итеп сакланган төрле материал, мәгълүматларны җыю, урлаудан гыйбарәт җинаятьчел эшчәнлек. *Галимҗан әфәнде Хәбибне, үз иленә кайткач, шпионажда гаепләп юк иттеләр.* И.Юзеев. *Берия шымчылары чит илләрдә атомга кагылган мәсьәләләр буенча зур эзләнүләр алып баралар, чөнки фәнни-техник шпионаж да НКВД карамагында була.* Ф.Бәйрәмова

**ШПИОНЛЫК** *и.* 1) Шпион булу. *Нәтиҗәдә комитетта эшләүче кайбер эмигрантлар Симаев әфәнденең шпионлыгына ышанырга да теләмәделәр.* Р.Мостафин

2) *к.* **шпионаж**. *Харьков камалышындагы трибунал да мине Ватанга хыянәт итүдә гаепләгән иде. Бусының да билгеләмәсе нәкъ шундый, аңа фәкать Германия файдасына шпионлык кына өстәлгән иде.* М.Әмирханов. *Казан дәүләт техник университеты (КАИ) доценты Әскәр Хөснетдиновның әтисен, шпионлыкта гаепләп, 1937 елда атып үтергәннәр.* Н.Алан

3) Берәр кеше артыннан күзәтеп, аның турында тиешле җиргә яки кешегә җиткереп тору эше. *Әмма Җәүдәт нык кына исерек иде, һәм ул кызны яклау урынына үзе һөҗүмгә ташланды: – Нәрсә син минем артымнан шпионлык итеп йөрисең?* Ф.Яруллин. *Хатын: «Мин барысын да беләм, сезнең икегезне бергә күрдем», – дип, тыныч кына җавап бирде. Бу сүзләр Илзинәнең ачуын тагын да кабартты: «Кара, бу безнең арттан шпионлык итә икән әле», – дип уйлады.* Айгизә

**ШПИОНЛЫ́К ИТҮ** *ф.* Шпионаж белән шөгыльләнү. *Комсомол өлкә комитетының беренче секретаре Галим Мөхәммәтҗанов японнар файдасына шпионлык иткән дип кулга алынгач, Шәрәфкә дә җиле тигән.* Л.Ихсанова. *Атласи --- җәзасыз котыла алмасын аңлый, шуңа күрә кайбер гаепләүләрне өстенә дә ала, әмма СССРны җимерергә теләү, шпионлык итү --- кебек гаепләрне кискен рәвештә кире кага.* Ф.Бәйрәмова

**ШПИОНЛЫ́К КЫЛУ** *ф. к.* **шпионлык итү**. *Син Ватанга хыянәт иткән һәм Германия файдасына шпионлык кылган өчен кулга алынасың.* М.Әмирханов

**ШПИЦ** *и. нем.* Очлы борынлы, үрә колаклы, озын куе йонлы этләр токымы. *Венера Мусинаның ике яшьлек померан шпицы токымлы эте шөгыльләре белән таң калдыра.* Байрак

**ШПОН** *и. нем. тех.* 1) Яфраклы агач токымнарының кәүсәсеннән буй юнәлештә бик юка итеп телеп алына, күбрәк мебель ясауда кулланыла торган агач катламы. *Моннан 5 ел элек алган урындыкларның кырыйларына ябыштырган шпоннары әллә кайчан кубып, коелып бетте инде.* Ә.Мөхәммәтҗанова. *Шуннан соң бүрәнәне үз күчәре тирәсендә әйләндереп, телү станогында тоташ юка йомычка – шпон кырдырыла.* Төзү материаллары

2) *полигр.* Наборда юллар яки сүзләр арасын киңәйтү өчен куела торган юка металл пластинка. --- *ике юлның арасына, хәрефләрнең койрыклары берберсенә бәрелеп тормасын өчен, шпон дигән нәрсәләр кыстырырга туры килә.* Г.Камал

**ШПО́НКА** *и. пол. тех.* 1) Төрле машина һәм механизмнарда әйләнә торган бер детальнең хәрәкәтен икенчесенә тапшыру өчен берсендәге уемга батырып куела торган озынча бармак, чөй сегмент яки теш рәвешендәге деталь. *Ул көймәне сулгарак аерды һәм озак та үтмәде моторы агач төбенә килеп менде, шпонка өзелде ---.* А.Гыйләҗев. *Слесарь: – Электерми инде алайса, – диде. – Я муфта, я шпонка кырылган.* Р.Кәрами

2) Ике янәшә тактаны бер берсенә беркетә торган агач теш, чөй рәвешендәге деталь

**ШПОР** *и. нем.* 1) Атны әйдәү өчен җайдакның күнитек үкчәсенә беркетелгән тешле яки шома тәгәрмәчле тимер дуга; типке. *Гали хәзрәт, шпорларын шалтырата биреп, югары таба менеп барган ротмистрга каршы килде.* Г.Ибраһимов. *Түземсезлек белән биеп торган тимер күк ат, шпорларны сизгәч, ук кебек атылып, алга омтылды.* Г.Әпсәләмов

2) Әтәч аягында арткы бармак, типке. *Сезнең әтәчегез бик әйбәт. Тик нигә аның шпорлары юк?* М.Мәһдиев. *Ләкин*

*бу турыда әйтергә авыз ачканда гына, Кәҗә Гайфиенең шпоры коелган карт әтәче бик ямьсез тавыш белән кычкырып җибәрде.* М.Шаһимәрданов

**ШПОРЛА́У** *ф.* Шпор белән корсагына тибеп атны әйдәү яки башка берәр команданы үтәтү. *Ә мин --- тузан басып киткән ялан аякларым белән чабышкымны шпорлагандай итеп, бөеренә төртеп алам ---.* Б.Рәүф. *Бу минутта аның тезгенне бушатып, чаптарының бөдрә ялына бөтен гәүдәсе белән иелгән килеш, камчылап, шпорлап --- билгесезлеккә каршы атыласы, очасы килә иде.* Мәйдан

**ШПОРЛЫ** *с.* 1) Шпор беркетелгән, шпоры (*1 мәгъ.*) булган. *Әгәр юлда очрасам, каршымдагы кызыл фуражкалы, шпорлы, яхшы френчлы --- бу җегетне минем Зәңгәр чишмәдәге дустым Шаһбаздыр дип ялгыш та уйлый алмас идем.* Г.Ибраһимов. *– Исән генә яшәүме? – диде ул, ишек катында шпорлы күнитекләренең табаннарын ышкыштырып.* М.Хәсәнов

2) Аягында шпоры (*2 мәгъ.*), типкесе булган. *Ишегалды чирәмендә кыткылдашып йөргән аклы-каралы тавыклар лапаска таба йөгерделәр, кызыл кикрикле зур ак әтәч кенә, --- шпорлы озын аякларының берсен күтәргән көйгә, ишегалды уртасында торып калды.* Г.Ахунов. *Тирән стресс кичергән зур кикрикле, --- шпорлы әтәч һаман да тынычлана алмый.* А.Хәсәнов

**ШПРИЦ** *и. нем.* 1) *мед.* Тәнгә сыек дару җибәрү, шулай ук сыеклыкны (мәс., *канны*) суырып алу өчен кулланыла торган пешкәкле цилиндр һәм шуның башына урнаштырылган эче куыш энәдән гыйбарәт инструмент. *– Зәйтүнә Мәҗитовна, кан тамырына эләгә алмыйм, – диде ул, кулындагы шприцны күрсәтеп.* М.Маликова. *Врач, төн тынлыгын бүлдерүдән курыккандай, сүзсез генә Рифкатьнең сул кулын сызгандырды, мамык белән ышкыды да шприцка дару суыртты.* Р.Вәлиев

2) Крем, май һ.б.ш.ны билгеле бер формада кысып чыгару өчен кулланыла торган махсус җайланма. *Куе йогуртны кондитер шприцына яки гади пакетка тутырабыз.* Шәһри Казан. *Крем ясау өчен, ингредиентларны яхшылап миксер белән болгатырга һәм профитроли камырына кулинар шприц белән крем тутырырга.* Йорт эшләре

3) *тех.* Машинаның аерым механизмнарын, күчәрләрен майлау өчен кулланыла торган пешкәкле цилиндр формасындагы инструмент. *Илһам гына комбайнын кабызмады. – Сез нишләп кузгалмыйсыз, Шаһзаманов? – диде Мирхәйдәров, аның янына килеп. – Мин моңа каршы, – диде Илһам, шприцына салидол тутыра-тутыра.* Ф.Садриев. *Комбайн ярдәмчеләре мәктәп укучылары --- ялга туктаган арада да кулларына кайсы ачкыч, кайсы майлау шприцы күтәреп, тирә-юньдә мәш килеп йөгерешәләр.* Р.Зарипов

**ШПРОТ** *и. нем.* 1) Сельдьчәләр семьялыгыннан диңгездә өер-өер булып яши торган вак промысел балыгы. *Ике башта да, як-яннарда, калай савытларда серкәләнгән сардинка, кефаль, шпрот балыклары җәелеп алынганнар.* Г.Исхакый. *Кальций җитешмәүдән котылу өчен климакс чорында хатын-кызга көн саен сөякләре белән ике вак балык (шпрот, сардина) ашарга кирәк.* Ватаным Татарстан

2) Шул балыкны яки башка төр вак балыкларны ыслап үсемлек маенда әзерләнгән консерв. *Минниса карчык газ өстендә тиз-тиз генә күкәй тәбәсе куырды, шпрот ачты, күмәч-мүмәчләрне телде, табын түгәрәкләнде.* А.Гыйләҗев. *Ленаның чемоданын карават астына шудырган арада, алдан ук хәстәрләп куелган җирдән --- бер банка шпрот тартып чыгарды Рафаэль.* Р.Мөхәммәдиев

**ШПУНТ** I *и. нем. махс.* 1) Такта, борыс һ.б.ш. әйберләрдә, ярык калдырмыйча бер-берсенә тоташып барсын өчен, махсус ясалган деталь; тырнак, теш // Шул юл белән ясалган тоташтыру ысулы

2) Гидротехник корылмаларда су юлын бикли торган койма ясау өчен агач, корыч яки тимер-бетон субайларны буе белән бер-берсенә ныклап беркетерлек итеп эшләнгән, ырмаулары булган субай. *Кыш булуга --- карамастан, --- дүрт мең кубометр җирне бер ай эчендә актарып ташларга, тирәли карлыгач койрыгыдай итеп шпунт кагарга --- кирәк.* А.Алиш. *Шпунтлар арасына соңгы кубометр бетон салу хокукын яулаган Виктор Калмыков бригадасын яр буенда бетон коючылар каршылады.* М.Рәфыйков

**ШПУНТ** II *и. нем.* Ташны беренчел эшкәртү өчен скульпторлар куллана торган зур өтерге

**ШПУНТЛАУ** I *ф.* 1) Такта, борыс һ.б.ш. әйберләргә шпунт ясау

2) Шпунт I (*1 мәгъ.*) ярдәмендә тоташтыру

**ШПУ́НТЛАУ** II *ф.* Шпунт кулланып нәрсә булса да ясау. *Булатов эшнең ничек барганлыгын баштанаяк сөйләп чыкты: – Без башта вакытлы буаны шпунтлап ясарга уйлаган идек. Такта юк, шуңар килеп терәлдек.* А.Алиш

**ШПУНТЛЫ** *с.* Шпунтлап ясалган, шпунтлары булган. *«Юрюзаньлес» предприятиесен ачкан Алмаз Исламгалиев күптән түгел спорт залы өчен шпунтлы такталар бирде.* Кызыл таң

**ШРАПНЕЛЬ** *и. ингл.* Эченә шарсыман пулялар яисә башка төр шартлаткыч матдәләр тутырылган; һавада ярыла торган артиллерия снаряды. *Ә менә мин --- нинди генә сугышларда, нинди генә атлы атакаларда булмадым... Ике тапкыр шрапнель белән яраландым.* Т.Гыйззәт. *Чынлап та, безнең шрапнель шәһәр читендә, позицияләр өстендә ярыла башлады.* Ш.Усманов

**ШРЕ́ДЕР** *и. нем.* 1) Кукурузның сабакларын чәкәннән аерып, чәкәннең тышчасын салдыра һәм аннан соң сабакларны турый, тапый, ваклый торган авыл хуҗалыгы машинасы

2) Кирәксез кәгазьләрне ваклау өчен офис җайланмасы

**ШРЕ́ДЕРЛАУ** *ф.* 1) Кукуруз сабакларын шредер (*1 мәгъ.*) ярдәмендә турау, тапау, ваклау

2) Кирәксез кәгазьләрне шредер (*2 мәгъ.*) ярдәмендә ваклау

**ШРИФТ** *и. нем.* 1) Текстны җыю (набор ясау) өчен кирәкле булган билгеле бер зурлыктагы һәм формадагы хәреф, билгеләрнең типографик литерлары комплекты. *Менә шушы Ральф төннәрен типография шрифтларын чәчеп ташлый, хәреф җыючыларны интектереп, күзгә бик чалынмый торган җирләрдә әкәмәт хаталар --- ясап куя, имеш.* А.Тимергалин // Типографик литерларның басылыш рәвеше; аларның кәгазьдәге эзе

2) Язуда хәрефләрнең график формасы. *«Шәригатьне торгызу шартлары» (---) китабы 2000 елда татар теленә тәрҗемә ителгән, A5 форматында газета шрифты --- белән басылган.* Р.Зарипов. *Эре шрифт белән җыелган мәкалә. Текстның калын шрифт белән аерылган өлеше*

3) Графикада, язуда авазларны белдерә торган билгеләр – хәрефләр комплекты. *Риза казыйның үз хезмәтләреннән дә берничәсен Мәдинә Рәхимкулова гарәп шрифтыннан кириллицага*

*күчереп, Казан белән Уфа нәшриятларына тәкъдим итте.* Л.Хәмидуллин. *Ә кайда тикшерәсең? Революциягә кадәр яки соңрак чыккан басмалардан, газета-журнал төпләмәләреннән, архив документларыннан, кульязма һәм башка төр чыганаклардан. Аларның күбесе төрле имлаларда, я гарәп, я латин шрифтында [язылган].* Р.Фәйзуллин

**ШТАБ** *и. нем.* 1) *хәрби* Гаскәрләр белән җитәкчелек итү органы һәм шул органга керүче кешеләр. *Ул Газинурга тагын нидер әйтергә җыенган иде дә, ашыгыч рәвештә полк штабына чакырдылар.* Г.Әпсәләмов. *Кибардин, тикшерербез, дип калды калуын да, ләкин Пермьнән яисә армия штабыннан ниндидер бик ашыгыч, бик мөһим күрсәтмә килеп төште ---.* В.Нуруллин

2) Шул орган урнашкан урын, бина. *Офицерлар шәһәрчегеннән солдатлар шәһәрчегенә – шунда ук штаб, --- каравыл йорты – чакрым ара чамасы гына.* Р.Сабиров. *Штабтан чыккач, урамда теге чактагы гөнаһлары өчен үкенеп барганда, берәү аңа: «Хәсип, брат!» – дип эндәште.* Р.Сәгъди

3) Гомумән нәрсәнең дә булса җитәкче органы. *Зур күтәренкелек, зур планнар белән төзелгән Язучылар союзы, яшәвенең беренче елларында ук бик нык сирәкләндерелсә дә, --- барыбер оешма булып сакланып кала алды, иҗат көчләрен мобилизацияләүче штаб ролен үтәде.* Р.Фәйзуллин. *Яңа шартларда сәнгать эшләре белән идарә итү өчен, 1930 елны Татарстан Мәгариф халык комиссариаты каршында Культура штабы төзелә.* Д.Гыйммранова

**ШТА́БЕЛЬ** *и. нем.* Бүрәнә, төзү материаллары һ.б.ш. нәрсәләрнең тигез итеп өелгән рәте, өеме, әрдәнәсе. *Үз эшеннән бүленеп, ул бригада кешеләрен челтәрләп штабельләргә өелгән кирпечләр янына алып килде ---.* Н.Фәттах. *Таһир белән Габбас пилорамнан чыккан такталарны штабельгә салып маташалар иде.* А.Хәсәнов

**ШТА́БЕЛЬЛӘҮ** *ф.* Нәрсәне дә булса штабель итеп әрдәнәләп өю. --- *Зәйнагов тумбочкага штабельләп өйгән дәфтәрләрнең беразын Фаяз алдына куйды.* Х.Камалов. *Утын дигәне штабельләп өелгән имән паркет булып чыкты.* Р.Вәлиев

**Штабельләп кую** Алдан яки тиз генә штабельләнгән хәлгә китерү

**Штабельләп тору** Даими, һәрвакыт штабельләү; хәзерге моментта штабельләү. *Ярылган такталарны штабельләп тору*

**Штабельли башлау** Штабельләргә тотыну

**ШТАБИСТ** *и. рус к.* **штабчы**. *Белемле, --- бик күп хәрби сорауларга тиз һәм төпле җавап таба белгән штабист бик тиз үсә башлый.* З.Зәйнуллин. --- *берәрсе авыруга тарыса, я көтелмәгән юлга чыкса, гадәттә, алмаш эзлиләр. Алмаш, билгеле, --- штабистлар арасыннан табыла.* С.Шәрипов

**ШТАБ-КВАРТИ́РА** *и. нем. хәрби* 1) Хәрби штаб урнашкан бина. *Үзенең штаб-квартирасын Сембергә күчергән Көнчыгыш фронты командующие Муравьёв шәһәрдәге коммунистик отрядларны тизрәк башка фронтларга күчерү чарасын күрә.* Г.Шәйхиева. *1942 елның 1 августында Гитлерның штаб-квартира начальнигы Кейтс имзасы белән инде төзелгән легионнарга тагын бер легионны оештырып кушарга дигән фәрман чыга.* З.Хәким

2) Нинди дә булса оешманың җыелу, җыелышу урыны. *Бөтендөнья рыцарьлар җәмгыяте штаб-квартирасы (Сидней, Австралия) карары белән әлеге җәмгыятькә әгъза итеп алына.* Р.Фәйзуллин. *Бу – Риф морза Акчурин. Татар дворяннарының, ягъни Татар морзалары мәҗлесенең җитәкчесе. Штаб-квартиралары монда аларның, Башкортстан башкаласында.* Я.Шәфыйков

**ШТАБ-ОФИЦЕР** *и. нем.* 1917 елга кадәр рус армиясендә һәм флотында полковник, подполковник, майор дәрәҗәсендәге офицерларга бирелгән дәрәҗә һәм шуңа ия булган кеше. *Күпчелек башкорт обер-офицер һәм штаб-офицерларының чиннары «Ранглар турындагы табель»гә ярашлы, тигезләштерелми, хезмәт итү вакытына гына бирелә.* Кызыл таң

**ШТАБС-КАПИТАН** *и. нем.-фр. хәрби* 1797–1917 елларда рус һәм кайбер башка чит ил армияләрендә пехота, артиллерия һәм инженерлык гаскәрләрендәге поручик һәм капитан арасындагы хәрби дәрәҗә һәм шуңа ия булган кеше. *Сез, атакай, күрәсең, улыгызның гомер буе поручик чинында интегүен телисез. Штабс-капитан кебек чиннар сезнең колакка ят ишетелә бугай.* Г.Ахунов. *Ул бит шул аклар арасындагы штабс-капитанның әтиәнисен көпә-көндез талап чыгып киткән иде.* Р.Сибат

**ШТАБЧЫ** *и.* Штабта хезмәт итүче офицер. *Дивизия тарафыннан кирәк-ярак белән азмы-күпме тәэмин ителгәч, үлгәннәр урынына штабчыларны һәм хуҗалык ротасындагыларны да сафка бастыргач, Жлобинны алырга кузгалып киттек.* Ш.Рәкыйпов. *Пөхтә штабчыбыз подполковник Алексей Петрович Щетинин беркөнне отрядтагы кешеләр исемлеген тикшерә ---.* И.Вергазов

**ШТАКЕ́ТНИК** *и. нем.* 1) Койма, рәшәткә ясарга яраклы махсус тар агач такта, планка. *Өй түре җимерекләргә рәшәткә корырлык штакетник, түбәсе китекләргә заводтан ук буяп кайтарылган профнастил --- өләшенде.* К.Кәримов. *Бераз хәл җыйгач, бригадир Мансур тиз генә торды да, штакетник алып, машинаның алгы тәрәзәсен сугып ватты.* Ә.Әминев

2) Шундый тактадан ясалган киртә, койма. *Әбиләрнең өе ике фатирлы булганга, йорт икегә бүлгән булып чыкты, бүлгән дигәнем, карыш ярым биеклегендә штакетник, ашасыннан атлап йөрергә була ---.* В.Ильясов

**ШТАМБ** *и. нем. махс.* Агач кәүсәсенең тамырдан алып ябалдашына кадәрге ботаксыз өлеше. *Әгәр дә агачның штамбы биек икән, берничә шешәне бер-берсе өстенә бастырып бәйләгез.* Шәһри Казан. *Фарсель Зыятдинов --- җимеш агачларын, корыган ботаклардан арындырып, кышка штамб, ягъни кәүсәнең аскы өлешен --- камыш, тукыма --- белән бәйләп калдырырга киңәш итә.* Авыл офыклары

**ШТАММ** *и. нем. махс.* Билгеле вирус, бактерия яки башка микроорганизмның изоляцияләнгән, аерым вакытта һәм аерым урында үскән, мөстәкыйль төр булып формалашмаган культурасы. *Моннан тыш, резистент штаммнарның таралуын даими күзәтеп тору, халык һәм медицина хезмәткәрләре арасында әлеге мәсьәләгә карата аңлату эшләре алып бару да мөһим.* Фәнни Татарстан. *Катнаш вакцина составына штамм, себер язвасы һәм тилчә вируслары керә.* Акчарлак

**ШТАМП** *и. ит.* 1) Гадәттә, эш кәгазенең сул яктагы югары почмагына басыла торган, җаваплы учреждение, оешма һ.б.ш.ның исеме язылган турыпочмаклык формасындагы штемпель, мөһер, пичәт. *Мөнирә кыр почтасының штампы сугылган зәңгәр конвертка, Таняның төзек хәрефләренә озак карап торды.* Г.Әпсәләмов

2) *тех.* Төрле әйбер, детальләрне серияләп, күпләп җитештерү өчен металл яисә башка материалдан эшләнгән калып, форма. *Үзем ук проектын биреп, совхоз тимерлегеннән штамп ясатып алдым да ходка җибәрдем.* М.Әмир. *Рәсемнәр яндырылмаган кызыл балчыкка алдан әзерләнгән агач яисә металл штамплар ярдәмендә төшерелгән.* Н.Фәттах

3) *тех.* Күн аяк киеменең төрле өлгеләрен кисү машинасы

4) Эшне бер рәвештә алып бару өчен билгеләнгән тәртип; әзер үрнәк, штамп, шаблон

5) *күч.* Күп кулланылган әзер схема, сукырларча иярә торган әзер үрнәк, шаблон, трафарет. *Әзер штампларга, калыпларга салып шигырь язучылар да җитәрлек.* Р.Миңнуллин. *Ул, әлбәттә, иҗат итү ысулын сәнгать мәктәбендә өйрәнгән, ләкин һәрбер эш өр-яңадан башлана, әгәр эшең бер төрле ысул белән генә башкарыла башласа, ул инде штампка әйләнә.* Н.Дунаев

**ШТАМПЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **штамплау**. *Беребез дә фәрештә түгел, холык-фигыль дигәне дә бер станокта штампланмаган – бәхәсләр булыр инде ул.* Р.Юныс. *1975 елның 10 сентябрендә беренче номерлы пресслар цехында беренче кайнар чүкелмә штампланды.* Казан утлары

2) *к.* **штамплашу**. *Минә шигъриятә иң күп кулланыла торган чәчәк образы. Ул мәхәббәтнең мәңгелек бер символы булып образлы фикерләүнең штампланган деталенә әверелгән инде.* Р.Харис. *Бәлки, «Шүрәле» мультфильмнарның нигез ташы булыр, бер ун елдан рәхәтләнеп, саф татар телендә «штампланган» маҗаралар карау бәхетенә ирешербез.* Безнең гәҗит

**Штампланып бетү** Артык штамплану. *Чыгышы күптән штампланып беткән фикерләрдән тора*

**ШТАМПЛА́У** *ф.* 1) Штамп сугу. *Хатларны штамплау*

2) Әзер калып, штамп (*2 мәгъ.*) ярдәмендә җитештерү. *Саф тимер – көмешсыман ак төстәге йомшак металл. --- Аннан штамплап, төрле фигуралы әйберләр ясап була.* Химия

3) *күч.* Күпләп җитештерү, кирәгеннән артык әзерләү. *Бүген безнең вузлар «белгечләр»не ел саен меңләп түгел, ә миллионлап штамплый һәм аларның күбесе эшсезләр армиясен тулыландыра.* Татарстан яшьләре

**Штамплап кую** Алдан ук яки тиз генә штамплау

**Штамплый башлау** Штампларга тотыну. *Миңнерәис Миңнесәет улы 2011 елда өч миллион сумга станок сатып алып, түбә калае штамплый башлаган.* Кызыл таң. *Прокурор протест ясагач, директор бер-бер артлы приказлар штамплый башлый.* Безнең гәҗит

**Штамплый тору** Даими, билгеле бер вакыт дәвамында штамплау. *Автомәктәпләр машина йөртү хокукын штамплый тора, фатиха биреп, полуфабрикат йөртүчеләрне юлга чыгара тора!* Әлмәт таңнары

**ШТАМПЛАШУ** *ф.* Шаблонга, штампка (*4 мәгъ.*) әйләнү, штамп (*4 мәгъ.*) булып китү; оригинальлеген югалту. *Заһид Сафич [образы] безнең әсәрләрдә әледән-әле күзгә чалынучы штамплашкан тискәре геройларга полемик рәвештә каршы тора.* Казан утлары. *Штамплашкан фикерләр. Штамплашкан гыйбарәләр*

**Штамплашып бетү** Тәмам, тулысынча штамплашу

**ШТАМПЛЫ** *с.* 1) Штамп (*1 мәгъ.*) сугылган, штампы булган. *Берара акчаның нольләре калькуляторларга сыешмады, кулдан-кулга «пачкалап» кына йөри башлады, билен буган штамплы кәгазе исән торса, кибетләрдә дә санамыйлар иде хәтта.* К.Кәримов. *Бюллетеньнәр штамплы күчмә урналарга салына.* Маяк

2) *к.* **шаблонлы 1.** (*2 мәгъ.*). *Миңа бервакыт: «Син рәсем ясарга өйрәнмәвең белән башкалардан бер башка өстен. Кануннарын, тәртипләрен белгән кеше штамплы әйберләр ясый башлый», – дигәннәр иде.* Шәһри Казан. *Характеристиканы төзүчеләр «әхлаклы», «әдәпле», «хатынын ярата», «өлкәннәргә булыша» дигән штамплы сүзтезмәләр кулланмаганнар.* Татарстан яшьләре

**ШТАМПО́ВКА** *и. рус* 1) Штамп (*2 мәгъ.*) ярдәмендә, әзер калып буенча күпләп җитештерү эше. *Кайнар штамповка. Салкын штамповка*

2) Штамп (*2 мәгъ.*) ярдәмендә эшләнгән әйбер, эшләнмә. *Деталь штамповкасы*

**ШТАМПО́ВКАЛАУ** *ф.* 1) Әзер калып, штамп (*2 мәгъ.*) ярдәмендә җитештерү. *Чөгендер алу комбайны өчен детальләр штамповкалау*

2) *күч.* Эшне бер рәвештә, әзер үрнәк буенча алып бару; шул рәвешле күпләп эшләп чыгару. *Берәү аранжировка штамповкалый, шагыйрьләр җыр текстларын тәкъдим итеп йөри...* Л.Заһидуллина

**Штамповкалап бетерү** Барысын да штамповкалау. *Эшләнмәләрне штамповкалап бетерү*

**Штамповкалый башлау** Штамповкаларга тотыну

**ШТАМПО́ВКАЧЫ** *и.* Штамповка эшен башкаручы эшче, белгеч. *Хатыны Галина Ивановна Казан авторемонт заводында штамповкачы булып эшли.* Биектау хәбәрләре

**ШТА́НГА** *и. нем.* 1) *спорт* Авыр атлетика белән шөгыльләнү өчен башларында билгеле авырлыктагы алынмалы дисклар булган металл күчәрдән гыйбарәт спорт әсбабы. *Бүксә калынаймасын дип, тегендә гер чөя идем, торам да штанга күтәрәм.* А.Гыйләҗев // Шундый җайланмалар күтәрүдән гыйбарәт спорт төре. *Туризм бит ул, әйтик, чаңгы спортындагы кебек, ун километр араны рекорд минутларда чабып уздың да спорт мастеры булдың яки, штангадагы кебек, йөз килограмм йөкне бер көчәнүдә баш өстенә чөйдең дә чемпион булу гына түгел.* А.Хәсәнов. *Университетка укырга кергәч, штанга секциясенә чакырдылар.* Н.Әхмәдиев

2) *тех.* Аерым механизмнарда металл күчәрдән гыйбарәт деталь. *Күкертле нефть клапаннарны ашый, торбаларны тизрәк туздыра, штангалар черек җеп кебек өзелә!* А.Гыйләҗев. *Мин ярда эшләгән арада корабларга нинди үзгәрешләр кергән? Җилкәнле кораблар калдырган мирас мачталар, аларны як-яктан тарттырып торучы вант, штангалар юкка чыккан.* М.Юныс

3) Футбол, хоккей һ.б.ш.да капка каркасы. *Ә туп исә, штангага эләгеп, яңадан кырга, футболчылар өеренә килеп төште.* Ә.Мушинский

**ШТА́НГАЛЫ** *с.* Штангасы (*2 мәгъ.*) булган, штанга ярдәмендә хәрәкәткә килә торган. *Девон скважиналары арасында штангалы насослар куллана торганнары да байтак.* Нефть турында хикәяләр. *Бу җайланма скважинада чумырыла торган насосларның озын штангалы приводларыннан котылырга ярдәм итә.* Татар заманы

**ШТА́НГАЧЫ** *и.* Штанга (*1 мәгъ.*) күтәрүче, авыр атлетика белән шөгыльләнүче спортчы. *Ул чакта Молдова чемпионнары арасында штангачы М.Кристуглы, көрәшчеләр Грекуглы һәм С.Күруглының гагауз егетләре*

*икәнлеген ишеткәч, соңгысын эзләргә керешүем хәтердә.* Т.Әйди. *Штангачы кебек таза гәүдәле баш инженер утырган урынында җиңелчә генә кыймылдап алды.* Ф.Абдуллин

**ШТАНГЕНЦИ́РКУЛЬ** *и. нем. тех.* Детальләрнең калынлыгын, киңлеген үлчәү инструменты. *Әле штангенциркуль белән үлчәп карамастан ук, Ишниязның бармаклары канатның бераз зуррак икәнен сизделәр.* Г.Әпсәләмов. *Таякның озынлыгын үлчәү өчен, миллиметрларга бүлемләнгән линейка, штангенциркуль (бер бүлеменең кыйммәте 0,1 мм) һәм микрометр (бер бүлеменең кыйммәте 0,01 мм) кулланганнар.* Алгебра

**ШТАНГИСТ** *и. рус к.* **штангачы**. *Штангист аларның уртак танышлары, сөйкемле һәм ипле егет иде.* А.Гыйләҗев. *Штангистлар, көн саен мунчага йөреп, үзләренең «артык» авырлыкларыннан арындылар.* Ф.Яруллин

**ШТА́ПЕЛЬ** *и. нем.* **1.** Төгенең озынлыгы белән мамык яки йонга охшаган синтетик сүстән тукылган материя. *Язгы чәчү вакытында, кыр станында безнең тракторчыларыбызны һич тоткарлыксыз тәмле-тәмле ашлар пешереп сыйлап торганы өчен, өлкән колхозчыбыз сөекле Мәрвибану апа Хәйретдинова бер күлмәклек штапель белән бүләкләнә ---.* Ф.Хөсни

**2.** *с. мәгъ.* Шундый тукымадан эшләнгән, тегелгән. *Өстенә авылчарак тегелгән алсу штапель кофта кигән.* Н.Фәттах. *Әнисе әле кичә генә тегеп бетергән, яшел җирлеккә сары чәчәкләр төшкән яңа штапель күлмәген кия.* Н.Көбәш

**ШТАТ** I *и. нем.* АКШта, Латин Америкасы илләрендә, Австралиядә, Һиндстанда: федерация составындагы үзидарәгә хокукы булган административ-территориаль берәмлек. *АКШта, нинди штат булуына карап, медицина иминияте балага уза алмауны дәвалауга киткән чыгымнарны тулысынча яки өлешчә үз өстенә ала.* Л.Габдрахманова

**ШТАТ** II *и. нем.* 1) Нинди дә булса учреждениедә эшләүчеләрнең даими составы. *Авыл кешесе фельдшерсыз да үлми, китапсыз да дуңгыз үстерә ала, дип штат кыскартып, экономия ясамакчылар.* Т.Миңнуллин

2) Нинди дә булса учреждениедә эш урыннарын, эшчеләр санын, эш хакын билгели торган документ. *Мин, аягүрә баскан килеш, бөтен шартын җиткереп: – Иптәш командир, – дидем, – үзегез дә беләсез, безнең ротада штат буенча бер генә писарь булырга тиеш.* Ә.Еники. *Республика революцион хәрби советының 8 октябрь приказы белән аның яңа штаты раслана, Политик бүлектә хезмәт итүче кешеләр саны 63 тән 158 гә кадәр җиткерелә.* И.Гыйззәтуллин

3) Шул документта каралган эш урыны, вакансия. *Николай Кузьмичның абруе Анастасиягә эшкә кергәндә дә ярдәм итте: ул сорагач, иң югары түрә юк җирдән штат бар итеп, хатынын шул ук базаның бухгалтериясенә эшкә урнаштырды.* Н.Әхмәдиев. *Аннары карчыгыңа да эш бар. Аңа да берәр штат табарбыз трест конторасында.* М.Мәһдиев

**ШТАТИВ** *и. нем. махс.* 1) Төрле прибор, химик колба, лаборатория савытларын тотып тору өчен махсус җайланма. *Әнвәр озын, тар өстәлнең караңгыда калган аргы очына, анда шәйләнгән штативларга, пыяла савытларга шикләнеп карады.* М.Маликова. *Әле һаман кайнап утырган колбаны штативтан бушатырга үрелдем...* З.Мифтахов

2) Нинди дә булса аппарат, приборлар беркетелә торган өчаяк. *Фотосурәтче штативка куйган аппаратның төймәсенә басканда, Рафиләнең соңгы дәресе тәмамланган һәм ул әлеге бүлмә каршысыннан узып бара иде.* Р.Рахман. *Ә беркөнне Җәмил Әхмәтша абыйсы янына фотоаппарат асып, өч аяклы агач штатив күтәреп килде.* Г.Шәрәфи

**ШТАТЛЫ** *с.* 1) Штатта II (*2 мәгъ.*) каралган, даими. *Профсоюз оешмасы сезнең хокукны яклый алыр, штатлы эшче итеп урнаштырыр.* С.Баттал. *Язучыны тәмам журналист итеп, йомышчы-хәбәрче итеп бетердек. Моның өчен газетаның штатлы корреспондентлары бар ич!* Ш.Галиев

2) Штаты II (*1 мәгъ.*) булган. *Моннан байтак еллар элек Татарстан китап нәшриятында марксизм-ленинизм классикларын тәрҗемә итү буенча шактый зур штатлы аерым бүлек бар иде.* А.Тимергалин

**ШТА́ТСКИЙ** *с. рус* 1) Хәрби яки полиция хезмәткәре булмаган. *Шулчак кибетебезгә атылып диярлек милиция киемендәге бер ханым һәм штатский берничә кеше килеп керде.* Ватаным Татарстан

2) Шундый кешеләр өчен характерлы, шундый кешеләрдә була торган. *Гата андый штатский тәртипләрне белгән кешемени, ишектән кергәч, бераз югалып калды.* М.Мәһдиев. *Аны шактый өлкән яшьләрдәге, өстенә штатский кием кигән пеләш башлы бер кеше каршы ала.* Р.Мостафин

**ШТЕ́ЙГЕР** *и. нем.* Рудниктагы эшләрне алып баручы мастер, техник. *[Розенбах:] Таныш булыгыз, безнең намуслы штейгерыбыз Гыйният әфәнде Галимҗанов.* Т.Гыйззәт. *Рәхәтләнеп алтын юам. Бер уймак булса, яртысы штейгерга. Атналыгы өч көн ашарга җитә.* Г.Сабитов

**ШТЕ́МПЕЛЬ** *и. нем.* 1) Мөһер, келәймә суга яки кире ягы белән уеп төшерелгән сурәтнең (язу, рәсем, имза кебекләрнең) оттискын ала торган әсбап; мөһер, пичәт. *Открыткалар һәм сувенир штемпель әлеге чарага махсус рәвештә Evolution агентлыгы тарафыннан чыгарылган.* Мирас

2) Шул әсбап ярдәмендә нинди дә булса документны раслау өчен яки башка максатлар белән сугыла торган билге, келәймә, пичәт. *Зәйтүнә конверттагы штемпельгә күз төшерде: хат Казаннан иде.* М.Маликова. *Бәхеткә каршы, ачык хатның өске ягында, почта штемпельләрендәге числолар ачык укыла.* Э.Сәгыйдова

**ШТЕ́МПЕЛЬЛЕ** *с.* Штемпель басылган, штемпель сугылган. *Берәр сәгатьтән палатага зәңгәр штемпельле кәгазь тотып Резеда Фәритовна килеп керде.* М.Маликова. *Штемпельле конверт. Штемпельле бланк*

**ШТЕ́ПСЕЛЬ** *и. нем.* Электр приборын (лампа, үтүк, суыткыч һ.б.) электр челтәренә тоташтыра торган ике яки өч япьле әсбап. *Телевизорда шартлау ишетелгән саен, хатынының дертләп куюын сизде Хәмидулла һәм, бу юлы Биктимердән дә сорап тормастан, штепсельне розеткасыннан суырып ук алды.* Д.Бүләков

**ШТИ** *и. рус сөйл.* 1) *к.* **щи**. *Мич ягылган, анда чуен-чуен кабыклы, әрчелгән бәрәңге утыра, кәбестә штие пешә.* А.Гыйләҗев

2) *диал.* Борчак, ясмык өйрәсе. *Бер капиталистик илнең эшсезе бушлай бүксәсе кап булганчы ясмык штие бөгә, икенчегә нибарысы кәбестәле сосиски ашаталар!* А.Гыйләҗев. *Тәмләп кенә җыйсалар да, берәр тапкыр шти пешерерлек борчак кайта торган иде.* М.Хәсәнов

3) *диал.* Гомумән шулпалы аш. *Шти, пирожки алып кердем.* Х.Туфан

**ШТИБЛЕТ** *и. нем.* Шнурлы яисә як-яклары резинкалы, гадәттә затлы ирләр ярымботинкасы. *Әлеге карт, авылны чыгу белән, атны туктата. Йөгереп кенә әрекмән арасына кереп китә, аннан чабата киеп, штиблетын төенчегенә төреп чыга.* А.Хәсәнов. *Габдулла абый бик пөхтә кеше иде, мәрхүм. Һәрвакыт ап-ак якага муенчак тагар, штиблетлары ялтырап торыр, шул штиблетларга карап кырынырга булыр иде.* Р.Батулла

**ШТИЛЬ** *и. голл.* Зур су (диңгез, зур елга, күл) өстендә тулы җилсезлек. *Эгей диңгезендә вак дулкыннар салмак кына уйныйлар иде. Ә Мәрмәр диңгезе безне штиль белән каршы алды.* М.Юныс. *Идел өстендә штиль хөкем сөрә.* К.Кәримов

**ШТИФТ** *и. нем. тех.* Нәрсәне дә булса хәрәкәтсез итеп тоташтыру өчен машина төзелешендә, медицинаның кайбер тармакларында һ.б.ш.да кулланыла торган цилиндр яки конуссыман кендек, башсыз кадак формасындагы деталь. *Танышымның медицина аппаратлары белән сәүдә итә торган ширкәттә эшләве билгеле булгач, штифтның 2 меңлеге дә сынган кул эченә сөяк ялгарга шәпләп кенә кереп урнашты, бөтен даруларга 2500 сум акча китте.* Шәһри Казан. *Этнең оча сөягенә штифт куелган, киселгән тәпие тегелгән.* Кызыл таң

**ШТОК** *и. нем.* 1) *геол.* Дөрес цилиндрик формада булмаган казылма байлыклар яки тау токымнары массасы. *Гранит штогы. Таш тозы штогы*

2) *тех.* Пешкәкле машиналарда пешкәкне шудырма белән тоташтыра торган кендек. *Ул, зур төгәллеккә ирешә алган хәзерлекле эшче, менә күп еллар буена инде бер детальне – шасси штокларын ясый.* Р.Фәизов. *Шток божрасы*

**ШТО́ЛЬНЯ** *и. нем.* Җир астындагы эш урынын җир өсте белән тоташтыра торган горизонталь яки сөзәк итеп эшләнгән коридор, җир асты юлы. *Диңгез өсте тигезлегеннән унбиш-егерме метрлар өскә күтәрелгәч, текә тау битендә – штольня.* А.Хәсәнов. *Егерме метрлап чәнечкеле тимерчыбык, кувалда алыгыз да тоннель өстендәге штольняның авызын киртәләп кайтыгыз.* С.Шәрипов

**ШТО́ПОР** *и. голл.* 1) Бер башы винтсыман итеп эшләнгән саплы бөке суыргыч. *Берәүдән сүзне штопор белән дә алыр хәл юк, берәүне бөке белән дә томалап булмый...* Ш.Галиев. *Резидә --- күршедәге төзелеш участогын саклаучы бабакайдан алып торган штопорны өстәлгә куйды.* Ф.Бәллүр

2) *авиа.* Самолётның текә спираль ясап түбәнәюеннән гыйбарәт югары пилотаж фигураларының берсе. *Иң тәҗрибәле очучыларыбыздан берсе булган капитан Клименко, штурман урынына утыртып, аэродром тирәли ике-өч әйләндереп төште үзен. Берочтан штопор һәм винт та ясап күрсәтә үзенә.* Р.Мөхәммәдиев // Җил яки берәр төзексезлек аркасында, самолётның идарәсен югалтып, үз көчәре тирәсендә әйләнә-әйләнә, бик кызу җиргә таба очуы. *Әле ун көннәр чамасы гына элек, шул самолётта штопорга эләгеп, чактан гына самолётны һәм үзен коткарып кала алды.* Р.Мөхәммәдиев. *Әлеге кадрларны өйрәнеп, белгечләр очкычның штопорга керү ихтималын фаразлыйлар.* Шәһри Казан

**ШТОР** *и. фр.* 1) Гадәттә, шнур ярдәмендә як-якка тарттырып яисә өскә менгереп куела торган, калын тукымадан озын итеп тегелгән тәрәзә пәрдәсе. *Келәмдә, артсыз кәвешләрен лыштырдата-лыштырдата, ишекле-түрле бик озак йөренгәч, тәрәзә шторын кулы белән читкә этеп, тышка карап торды.* Г.Әпсәләмов. *Аның бар курыкканы кояш нуры иде һәм шуңа күрә аның бүлмәсенә беркайчан да диярлек кояш нуры кертелми, шторлар һәрвакыт төшерелеп тора иде.* Н.Фәттах

2) Калын тукымадан яки башка төрле материалдан тегелгән тәрәзә яки ишек пәрдәләренең гомуми атамасы. *Бүлмәнең тәрәзәсенә дә, ишегенә дә затлы шторлар асканнар*

**ШТО́РА** *и. фр. к.* **штор**. *Анда тагы бер бүлмә бар бугай. Ишегендә яшькелт бәрхет шторалар.* Х.Камалов. *Кинәт тәрәзә ачылып китте дә бүлмәгә, нечкә алтын җептән тукылган озын өрфия шторaларны кабартып-җилфердәтеп, дымлы җил бәреп керде.* З.Мәхмүди

**ШТОРМ** *и. голл.* Гадәттә диңгез өстендә күтәрелгән көчле җил, давыл. *Тын океанның дәһшәтле штормнары!* М.Мәһдиев. *Диңгезләрне сез яхшы беләсез инде, егетләр, анда туктаусыз штормнар булып тора.* Ф.Яруллин

**ШТОРМО́ВКА** *и. рус* Калын, тыгыз, су үткәрми торган материалдан тегелгән капюшонлы куртка. *Резин итекләр өстерәп, штормовка киеп, мин фермадан кайтып барганда, бухгалтер хатыны һәр көнне, җимеш бакчасының капкасыннан башын тыгып, мыскыллы елмаеп кала.* М.Мәһдиев. *Юрий Петрович иңбашындагы винтовкасын агач ботагына элде. Чаңгысын, калын штормовкасын, җылы тире бияләйләрен салды.* А.Хәсәнов

**ШТОРМТРАП** *и. голл. диңгез.* Шторм вакытында кешеләрне судногa алу яки төшерү өчен агач басмалы бау баскыч. *Без, штормтрапка асылынып, көймәгә төшәбез. Кызның --- аягында биек үкчәле босоножка. Мондый аяк киеме белән штормтраптан төшеп булмый.* М.Юныс

**ШТОФ** I *и. нем. иск.* 1) 1/10 чиләк күләменә тигез сыеклык үлчәү берәмлеге. *Фәттах акчаны кызганмады. Балның эченә бер штоф акны алып кайтып кушты.* Ә.Фәйзи. *Шулвакыт Мәрхәмбикә: – Бар, үзеңә берәр штоф ал, – дип каяндыр чыгарып, Хәмитнең учына илле тиенлек көмеш салды.* М.Хәсәнов

2) *сөйл.* Шул күләмдәге дүрт кырлы аракы яки шәраб шешәсе. *Әрҗә эченнән башланмаган бер штоф аракы чыгарып бөкесен ачты.* М.Хәсәнов. *Швед эчемлеге «Абсолют»тан бушаган ике буш штофка караганда, шактый утыралар булса кирәк, табыннары да бик бай күренә иде.* Р.Мирхәйдәров

**ШТОФ** II *и. нем.* **1.** Өй җиһазларын тышлау, шторлар ясау һ.б. өчен кулланыла торган, тукып рәсем төшерелгән калын авыр йон яки ефәк тукыма. *Карчык (төеннәрене чишеп, чыгарып өстәлгә куя). – Менә монысы – асыл. Кирәк булса, штоф та бар.* Г.Исхакый. *Бай, алтынланган куе чия төсендәге штоф тукымасы белән тышланган Прибытков кабинеты.* Ф.Халитов

**2.** *с. мәгъ.* Шул тукымадан тегелгән. *Димләгез кызның чибәрен, егет үзе сөйгәнен; Алтын алка, чылбыр яка, штоф камзул кигәнен.* Җыр. *Штоф шторлар*

**ШТРАФ** *и. нем.* 1) Җәза рәвешендә административ яки суд тәртибендә түләтелә торган акча. *Әскәйдә әнә корыган агач, черек төп алып кайтсаң да, тотыла калсаң, авыл советына чакыртып, акт төзиләр, штрафы белән янә бер кат ыштаныңны салдыралар.* Н.Әхмәдиев. *--- комиссия ул сиңа бер Илүсә генә түгел! Аңа, гадәттә, бик чая апалар кергән була, һәм алар таләпне дә каты куя, штрафны да саллы чәпи.* М.Маликова. *Иптәшләр судында быел гына да унбер эш каралды һәм унҗиде колхозчы эчүчелек белән шөгыльләнгәне өчен штрафка тартылды.* Т.Нәҗмиев

2) Терминологик сүтезмәләрдә килеп, «дисциплина бозган яки җинаять кылган өчен хәрбиләргә уен шартларын, кагыйдәләрен яисә этикетны бозган спортчыларга бирелә торган җәза» мәгънәләрен белдерә. *Әмма суд, гаепләнүченең моңарчы андый эшләр белән шөгыльләнмәвен һәм үрнәк эшче булуын исәпкә алып, ул хөкем карарын үзгәртергә, ягъни хәрәкәттәге армиядә бер ел штраф батальонында хезмәт итү белән алыштыруны мөмкин дип тапкан.* М.Хәсәнов. *81 нче минутта штраф мәйданыннан Сальваторе Боккетти тибеп керткән туп шактый бәхәсләр уятты.* Шәһри Казан. *Баштан ук безнең спортчыларның өстенлеге бәхәссез иде: судья билгеләгән штраф тубын Кирилл Королёв кертте.* Яңа тормыш

**ШТРАФНИК** *и. рус к.* **штрафчы**. *Регуляр армиягә күчкәнче, ел ярым эчендә миңа штрафниклардан унөч рота тупларга туры килде ---.* Г.Галиев. *Дивизиядию дөрес булмас, ә «кыргый» дигәне шикләндерми. Аннан-моннан җыелган штрафниклар иде. Хәтта моряклар да бар иде араларында.* С.Сабиров

**ШТРАФЧЫ** *и.* 1) Штраф ротасына һ.б.ш. частьларга җибәрелгән хәрби. *Бүтән суднолардан куылган төрле штрафчыларны --- безгә җибәрәләр.* С.Сабиров. *Лагерь уртасында зур гына сазлык бар. Фашистлар, штрафчыларны менә шунда куып кертеп, сәгатьләр буе тез тиңентен баткакта йөртәләр.* С.Таҗетдинов

2) Спорт уеннарында кагыйдә яисә тәртип бозган уенчы. *Хоккейда очрый торган бик сирәк хәл: алтмыш минут дәвамында уенчылар бер тапкыр да кагыйдә бозмадылар, бер тапкыр да штрафчылар эскәмиясенә утырмадылар.* Шәһри Казан

**ШТРЕЙКБРЕ́ХЕР** *и. нем.* 1) Забастовка вакытында эшләп, забастовкачылар мәнфәгатьләрен сатучы кеше. *Алар арасыннан провокаторлар, штрейкбрехерлар [чыкты].* Г.Ибраһимов. *Ахырда хезмәт хакын күтәрделәр күтәрүен, тик унлап эшчене төрле срокка төрмәгә яптылар. Үзара сөйләшүне бозып заводта эш башламакчы булган адәмнәрне, ягъни штрейкбрехерларны тотып кыйнаган өчен.* Р.Фәизов

2) Гомумән хыянәтче, антын бозган кеше. *– Эх, сез! Җебегәннәр, штрейкбрехерлар! Бер төнгә түзмәделәр. Ант итәләр, имеш. Менә ышан сезгә!* Т.Миңнуллин

**ШТРЕЙКБРЕ́ХЕРЛЫК** *и.* Забастовка вакытында, эш ташламыйча, эшчеләр мәнфәгатенә хыянәт итү күренеше; гомумән, эшчеләр сыйныфы мәнфәгатенә хыянәт. *Болар эш ташлау хәрәкәтендә штрейкбрехерлык ролен үтәмәсеннәр дигән курку бар.* Г.Ибраһимов

**ШТРЕК** *и. нем.* Шахта, рудник һ.б.ш.да җир өстенә вертикаль чыгу урыны булмаган, файдалы казылма катлавы буенча ясалган горизонталь коридор. *Таһирлар ул көнне маркшейдер Пьер җитәкчелегендә яңа штрек ачтылар.* А.Хәсәнов. *Өстәге штректан утыз метрлап аска төшеп, бораулап шартлаттылар. Әмма скважинадан газ чыкмады, күмер тыгылган иде.* Д.Каюмова

**ШТРИХ** *и. нем.* 1) Беленер-беленмәс итеп сызылган нечкә өзек-өзек сызыклар. *Өлгедә сызыклар хасил булды. Алар бер генә яклы түгел, ә төрлесе төрле тарафка караган – өзек-өзек штрих кебек.* Р.Кәрами // Шундый сызыкларның берсе. *Клара бер штрих төшердеме, бер сызык сызып куйдымы – барысы да экранда.* А.Хәсәнов

2) Кәгазьдәге текстта булган хаталарны төзәтү өчен кулланыла торган махсус сыек ак буяу. *Татарстан машина йөртүчеләре үз номерларын видеокамералардан яшереп, --- номерлардагы кара буяуны сөртәләр яки канцелярия штрихы белән буяп, хәреф һәм саннарны үзгәртәләр.* А.Уваров

3) *күч.* Кемне яки нәрсәне дә булса характерлый торган сыйфат, үзенчәлекле деталь. *Рәссамнар кайбер картиналарын гомер буе язалар, гомер буе яңа штрихлар өстиләр, ди бит.* Ф.Яруллин. *Тәнкыйтьче, аерым штрихлар белән унга якын шагыйрьнең иҗат юнәлешләрен яисә кайбер табышларын күрсәткәннән соң, мондый нәтиҗәгә килә ---.* Ә.Закирҗанов. *Нәҗип хәзрәтнең тәрҗемәи хәленнән бер кызыклы штрих.* Р.Әмирхан

**ШТРИХКОД** *и. рус* Товар, билет, кредит карточкалары һ.б.ш.га салына һәм махсус аппарат ярдәмендә автомат рәвештә укыла торган төрле калынлыктагы аркылы сызыклардан гыйбарәт шартлы билге, тамга, маркировка, штрихлы код. *Шешәне пандоматка салу өчен аның штрихкоды булу – төп шарт.* Әлмәт таңнары

**ШТРИХЛА́У** *ф.* 1) Штрихлар, нечкә өзек-өзек сызыклар сызу. *Координаталар турысында аралыклар берләшмәсен штрихлап күрсәтегез ---.* Геометрия. *Рәсемнәрне төрле юллар белән буяп (штрихлап) була.* Сөембикә

2) *күч.* Нәрсәнең дә булса сыйфатында үзенчәлекле деталь күрсәтү; әкренләп, аерым детальләр белән тасвирлау. *Ул, күпчелек замандаш шагыйрьләре кебек, заман, тарих портретын штрихлап, берәмтекләп язмый, аны укучы күңеленә бөтен килеш, бөтен, җанлы сурәт рәвешендә иңдерә.* Г.Гыйльманов

**Штрихлап бетерү** Тулысынча, башыннан ахырына хәтле штрихлау. *Рәсемне штрихлап бетердем*

**Штрихлап кую** Алдан штрихлау, штрихлаган хәлгә китереп калдыру. *Эскизларны штрихлап кую*

**Штрихлап чыгу** Тулысынча, башыннан ахырына кадәр штрихлау

**ШТУКАТУР** *и.* 1) Штукатурлау эшләрен башкаручы кеше, шул эшнең остасы. *Икенче кыз исә шәһәрдә штукатур булып эшли һәм байтак акча ала, әти-әнисенә гел ярдәм итеп килә.* М.Мәһдиев

2) *к.* **штукатурка** (*2 мәгъ.*). *Квартирага берничә ел буена ремонт ясатмадылар: теш чыккан вакыттамы икән, Назирә коридор стенасыннан штукатур ашады.* М.Мәһдиев. *Шушы яңа төзелгән бүлмәләрне штукатур белән капларга ике кыз килде.* Ф.Йосыпов

3) *к.* **штукатурлау** (*1 мәгъ.*). *Штукатур эше җиңел түгел, анда барырга атлыгып торган кеше юк.* Р.Вәлиев

**ШТУКАТУ́РКА** *и. ит.* 1) Штукатурлау эше. *Кызның штукатуркага кулы ятып тора шул, ул эшне бик әйбәт башкара*

2) Төзү материалы буларак, бина һәм корылмаларның стеналарын сылау, тигезләү өчен кулланыла торган махсус куе измә // Шул измәнең сылаганнан соң каткан катламы. *Сабир штукатуркасы кубып, акшары каралып беткән юыну бүлмәсендә үзенең тастымалларын юа иде.* Г.Әпсәләмов. *Сугышка киткән егетләрнең штукатуркага карандаш белән язган соңгы эзләре җебеде.* М.Мәһдиев

3) *күч. гади с.* Биткә калын итеп сөрткән крем, кершән, пудра катламы. *Син... давай, чамалап... --- Син сылаган хәтле штукатурка сыласаң, сиксән яшьлек карчыктан да Снегурочка ясап була.* З.Хәким

**ШТУКАТУРЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **штукатурлау** (*1 мәгъ.*). *Бинаның*

*матчалары агачтан гына, түшәме такта һәм штукатурланган, эчтән янә декоратив тышланган.* Р.Зарипов

2) *күч. кайт. юн. к.* **штукатурлау** (*2 мәгъ.*). *Болар барысы да Низаметдин күңеленә сары май булып ятты, чөнки артык ясанган-бизәнгән, үзе әйтмешли, «штукатурланган» хатын-кызларны җене сөйми аның.* Ә.Сафиуллин

**ШТУКАТУРЛА́У** *ф.* 1) Бина яки корылма стеналарын, түшәмнәрен штукатурка (*2 мәгъ.*) белән каплау, штукатурка сылап тигезләү. *Ике хатын, кузла өстенә басып, бәләкәй көрәкләре белән сыекча бәрә-бәрә, түшәм штукатурлыйлар иде.* Г.Әпсәләмов. *Бүлмәне штукатурлый торган кызларның берсе аягын сындырган, икенчесенең сул кулы имгәнгән һәм битләре җәрәхәтләнеп беткән иде.* Ә.Сафиуллин

2) *күч. гади с.* Биткә төрле крем, кершән, пудра кебек нәрсәләрне күп итеп сылау, акшарлау, зәвыксыз бизәнү. *«Шулай матур» дип, кат-кат тоналка белән бетчә штукатурлап йөрүче кызларда минем эшем юк бит.* Шәһри Казан

**Штукатурлап бетерү** Тулысынча штукатурлау. *Таң атканда коены штукатурлап бетерделәр.* Р.Вәлиев

**Штукатурлап җибәрү** Бераз штукатурлау; штукатурларга да өлгерү

**Штукатурлап кую** Алдан штукатурланган хәлгә китерү. *Хәзер инде нигездәге каберташларның язуын штукатурлап ук куйганлыктан, аларны бөтенләй күреп булмый.* Ф.Ислаев. *Авыл уртасында кирпеч йорт сатып алганнар, кыш көне җылырак булсын дип, штукатурлап та куйганнар.* Кайбыч таңнары

**Штукатурлап чыгу** Барысын да штукатурлау, бер җирне дә калдырмыйча штукатурлау; башыннан ахырына кадәр штукатурлау. *Җентекләп ремонтлау өчен, йортның ярыкларын ябыштырып, штукатурлап чыгасы бар.* Шәһри Казан

**Штукатурлый башлау** Штукатурларга тотыну. --- *өч көн эчендә дә шактый нык эшләп ташлаганнар иде: түбәне ябып бетереп киләләр, ишектәрәзәләрне куя башлаганнар, озакламый штукатурлый башлаячаклар икән.* М.Маликова

**ШТУКАТУРЛЫК** *и.* Штукатур һөнәре яки кәсебе

**ШТУКАТУРЧЫ** *и. сөйл. к.* **штукатур**. *Безнең төзелештә монтажниклар, штукатурчылар, электросварщиклар курсы бар, теләгәненә керергә була.* Т.Гыйззәт. *Иртәгә инде монда штукатурчылар йөгереп йөри башлар, ә ташчылар күрше йортка күчәчәкләр...* Г.Әпсәләмов

**ШТУКАТУРЧЫЛЫК** *и. сөйл. к.* **штукатурлык**. *Суфия белән Маһинур баштa кара эшче булып, аннары бетонщица булып эшлиләр, штукатурчылык һөнәренә дә шунда өйрәнәләр.* Г.Әпсәләмов

**ШТУРВАЛ** *и. голл.* 1) Комбайн, судно, самолёт, трактор һ.б. транспорт чараларында һәм машиналарда руль тәгәрмәче. *Пилотның куллары штурвалда, ә башы бер якка салынып төшкән.* Г.Әпсәләмов. *Иң алдынгысы булмаса да, ун-унбиш ел буе комбайн штурвалы тотып шомарган абзыйлардан әллә ни калышмады ул.* Г.Гыйльманов. *Кораб Елантау ярына якынайгач, штурвал артында Пётрның үзе килгәне күренде.* В.Имамов

2) *күч.* Җитәкчелек; идарә итү эше; дилбегә. *Һәркайсыбыз булдыра алганча эшләргә һәм мөмкин кадәр күбрәк эшләргә тиеш. Ә синең «Ватан»да эшләрлек сәләтең барына мин ышанам. «Чулпан»да калдыра алмыйбыз без сине. «Ватан» штурвалын тоттырмакчы булабыз.* В.Нуруллин

**ШТУРВАЛЧЫ** *и.* Штурвалда торучы, шуның ярдәмендә идарә итүче кеше. *Безнең телгә чая штурвалчы кыз Җәмилә үзе юкта Мидхәт агайны Мыеклы түти дип йөртә...* С.Сабиров. *Штурвалчы булу өчен, әллә ни белем кирәкми бит инде.* А.Хәлим

**ШТУРВА́ЛЬНЫЙ** *и. рус сөйл. к.* **штурвалчы**. *Команда исеменнән сезгә бу хатны пароходның штурвальные, һәрвакыт Мәрьям Вәсилевна белән бергә рубкада вахта торган --- Җәмилә Бәхтиярова яза.* С.Сабиров

**ШТУРМ** *и. нем.* 1) Дошманның кальгасына, ныгытылган позицияләренә хәлиткеч һөҗүм. *Газинур тавыш басылганны көтте дә укуын дәвам итте: – Һәм Смоленскига бару юлында немецларның мөһим терәк пункты – Духовщина шәһәрен штурм белән алдылар.* Г.Әпсәләмов. *Сталинградны немецлар дүрт көн буе бомбага тоттылар. Аннары штурм башланды.* Ф.Зыятдинов

2) *күч.* Билгеле бер максатка ирешү өчен яки берәр кешегә каршы эшләнгән тәвәккәл эш, актив хәрәкәт. *Автобус тукталышында кара яу кебек халык төркемен күрдем. Машина килеп туктауга, этешә-төртешә, кычкыратиргәшә, штурм белән яулап кереп утыралар.* Л.Ихсанова. *Яңгыр түгел, таш яуса да, тапшырыласы объектларны тапшырып бетерергә – бездән бары менә шушы гына сорала. – Айлар буе эленке-салынкы йөрибез дә, квартал азагы җитүгә, тагын штурм башлана.* Р.Вәлиев

**ШТУРМАН** *и. голл.* Су яки һава судноларында, космик корабль, узыш болиды кебек транспорт чараларының ориентлашуы, урынын һәм маршрутын билгеләү эше өчен җаваплы экипаж әгъзасы. *Елгачыны Галләм Галиев дип йөртәләр икән. Үзе яр буенда торучы «Бурлак» пароходында беренче штурман булып эшли, хәзер авылда үлгән энисен күмеп кайтып килеше икән.* С.Сабиров. *Бу коточкыч хәлне миңа озак еллар диңгездә, сәүдә флотында штурман булып йөзгән егет сөйләде.* А.Хәсәнов

**ШТУРМАНЛЫК** *и.* Штурман булу; штурман вазифасы, хезмәте. *Буш вакытларың чыкканда, безнең «Штурманская»га кереп утыргала. Теләсәң, штурманлык сәнгате белән дә таныштырырмын.* А.Хәсәнов. *Штурманлыкка укуны да ул шушы олы хыялына ирешү юлында чираттагы этап буларак кабул итте.* Р.Мөхәммәдиев

**ШТУ́РМЛАУ** *ф.* 1) Штурм ясау, атакага бару, һөҗүм итү. *Кызыл вагоннарның тәрәзәләреннән, ачык ишекләреннән сугышып йөргән яшел урманнар, штурмлап алынган полустаноклар, янган, җимерелгән станцияләр күренеп кала.* Г.Әпсәләмов. *Ул Мәскәүне саклаган, Берлинны штурмлаган, Праганы азат иткән.* З.Зәйнуллин

2) *күч.* Билгеле бер максатка ирешү өчен тәвәккәл эш итү, актив хәрәкәт ясау. *Маршрутны гына күр әле. Төньяк Карелия, Кола ярымутравы буйлап бит! Синең ул якларда булганың юктыр. Моңарчы без күбрәк Уралны, Алтайны, Кырым-Кавказны штурмладык. Күреп тә, ял да итеп кайтырсың.* А.Хәсәнов. *Мәркәзебезнең Филармония залында узган Рэн Кунинның «666 нумер» комедиясен, халыкның тамаша залын штурмлаганын күргәч, шулай уйлап куйдым.* А.Шәймәрданов

**Штурмлап карау** Штурмларга тырышу; нәтиҗәсен белү өчен штурмлау. – *Кенәз каланы ялгыз көе генә штурмлап карасын. Әгәр яулый алса, даны да, байлыгы да берүзенә булыр! – диде.* В.Имамов. *Минзәлә крепостен Каранай Муратов җитәкчелегендәге 10 мең кешелек фетнәчеләр отряды*

*дүрт ай буена камалышта тота. Берничә тапкыр штурмлап та карыйлар, әмма ала алмыйлар*. Татарстан тарихыннан хикәяләр

**Штурмлап тору** Даими яки әледәнәле штурмлау, әле хәзер штурмлау процессында булу

**Штурмлап яту** *сөйл. к.* **штурмлап тору**. *Прокурорның сак колагы егетләрнең аяк астында нидер шыртлаганын, коелганын ишетте, алар инде икенче катны штурмлап яталар иде, күз кырые белән стенада фонарь яктысын күрде, әмма бина ишегеә ишегалдына таба ачылмады*. Р.Мирхәйдәров

**Штурмлый башлау** Штурмларга тотыну. *1945 елның апрель урталарында Гитлерның резиденциясен – Империя канцеляриясен подполковник Исхак Идрисович Гумеров җитәкчелегендәге 1050 нче укчы полк солдатлары штурмлый башлый*. А.Хәсәнов. *Кызыл командирлар Блюхер, Грязнов, Корк, Миронов, Уборевич, Будённый командалык иткән дивизия һәм армияләр Кырымны штурмлый башлый.* З.Зәйнуллин

**ШТУРМОВИК** *и. рус* 1) Дошман көчләренә каршы зур булмаган биеклектән һөҗүм итә торган хәрби самолёт. *Авыл өстеннән көнбатышка таба безнең штурмовиклар очып үтте.* Г.Әпсәләмов

2) Шундый самолёт белән идарә итүче очучы. *Әмма штурмовиклар частена урнашырга китерелгәч, Әнвәр тагы бер гаҗәп хәлгә тап булды*. Х.Камалов

**ШТУРМЧЫЛЫК** *и.* Үтәлми калган эшләрне бөтен көчне туплап, ашыкпошык, аннан-моннан эшләү гадәте; шулай эш итү принцибы. *Бик күп мөһим эшләр әнә шундый «дәррәү кампанияләр» өянәгенә, штурмчылыкка килеп эләгә.* Г.Ахунов. *Штурмчылык, кода-кодагыйлык, кадрлар алмашынып тору, кирәкяракның үз вакытында кайтартылмавы, акчаны әрәм-шәрәм итү, башбаштаклык, хуҗасызлык, тәртипсезлек – каян килсен ди сыйфат?* Шәһри Казан

**ШТУРТРОС** *и. голл. диңгез.* Суднода штурвал хәрәкәтен рульгә тапшыра торган чылбыр яки трос. *Кинәт штуртрос өзелеп, штурвал сафтан чыкты.* С.Сабиров

**ШТУФ** *и. нем. махс.* Нинди дә булса тау токымы, руда, минералның сынау, тикшерү яки коллекция өчен әзерләнгән зур булмаган кисәге

**ШТУЦЕР** *и. нем.* 1) Ике көпшәле эре калибрлы ау мылтыгы

2) *тех.* Торбаларны бер-берсенә тоташтыру яисә резервуар, савыт һ.б.ш.га борып кертү өчен махсус сырлы торба кисәге. *Штуцерларны алып ташладык. Нефть ташкын кебек ага.* А.Хәсәнов. *Түбән Кармалка авылы янындагы торба үткәргеченнән эшермәләрнең ике штуцеры югалган.* Безнең Чирмешән

**ШТЫК** *и. пол.* 1) Мылтык яки винтовка көпшәсенең очына кидерелгән чәнчә торган салкын корал. *Очлы штыкның якында гына печәнне кисеп кергәне тоелды.* А.Расих. *Зәйни, Долгушев, Стародубцев – өч дус, сүз берләшеп тормыйча, окоптан сикерешеп чыктылар да, иңнәрен бер-берсенә терәп, штыкларын алга сузып, финнарга каршы үзләре ташландылар.* З.Зәйнуллин

2) *иск.* Сугышчан берәмлек буларак пехотада хезмәт итүче солдат, пехотачы. *Безнең полкның роталары бик аз штыклы... 120 штыкка тулыр-тулмас кына.* А.Таһиров

3) *күч.* Гомумән сугыш коралы, хәрби көч. *– Англия-Америка капиталистлары, – диде ул, – безнең революцияне ак бандалар штыгы белән үтереп ташларга телиләр.* И.Гази. *Фронтта да байтак язучыларыбыз, каләмне штыкка тиңләп, алгы сызыктагы сугыш операцияләрендә катнашу белән бергә, фронт газеталарын чыгаралар.* Р.Фәйзуллин

◊ **Штыкка алу** 1) Штык белән кадап үтерү. *Нык карагыз! Берсен дә качырмаска. Тегенди-мондый хәл булса, штыкка алырга.* Г.Бәширов; 2) Ризасызлык белдереп, кискен рәвештә каршы килү. *И.Нуруллин мәкаләсен штыкка алу кирәк идеме?!. Мин, И.Нуруллин әдәби мирасыбызны бәяләүдә фәнни объективлык булырга тиеш, дигән әһәмиятле мәсьәлә күтәрде ---, дип саныйм.* З.Мәҗитов. **Штыкка кадау** *к.* **штыкка алу** (*1 мәгъ*). *Бөтен иске дөньяны тетрәтеп, «Аврора»дан туплар аткач та, --- алар үзе шикелле үк --- соры шинельле кешеләр белән бергәләп, --- берниди шикләнүсез ак офицерларны штыкка кададылар да большевиклар ягына чыктылар.* Н.Фәттах. **Штыкка күтәрү** 1) *к.* **штыкка алу** (*1 мәгъ*). *Бер контрактникның җимерекләр арасында калган коляскадагы баланы ничек штыкка күтәрүе турында да әйтте.* З.Мәхмүди; 2) Көлү объектына әйләндерү, көлкегә калдыру. *Егетләргә симпатияңне белдерергә дә ярамый. Шундук штыкка күтәрергә торалар. Ничек яшәргә инде хәзер?* А.Хәсәнов

**ШТЫКЛЫ** *с.* 1) Штыгы булган, штык белән коралланган. *Аларны кырык тешле штыклы өч фин солдаты каршы алды.* З.Зәйнуллин. *Өйгә иң элек штыклы мылтыкларын алга төбәгән дүрт солдат бәреп керә.* Р.Мөхәммәдиев

2) *күч.* Зәһәр, усал. *Чын шагыйрьнең кендеге халык белән тоташкан була: шушы наив, самими, саф хиссият белән тулы әсәр коры тезмәләрдән, штыклы шигырьләрдән алҗыган татар кешесенең иң нечкә күңел кылларына кагыла.* И.Юзеев

**ШТЫРЬ** *и. нем. тех.* 1) Зур калын кадакка охшаган очлы деталь. *Шигырь булып туды әманәтем, Штырь булып чыкты хәсрәтем, Матурлыкка – чиксез мәхәббәтем, Явызлыкка – чиксез нәфрәтем.* Г.Афзал. *[Гәрәй] каркас баганалары утырачак урыннарда калдырылган тимер штырьларны тартыптартып карый.* А.Гыйләҗев

2) Конуссыман очлы кечерәк тимер кендек. *Штырь һәм втулка стеналарындагы бакыр боҗраларга кабель чыбыклары ябыштырып куелган була.* Нефть турында хикәяләр

**ШУ** I *ияpт. к.* **жу**

**ШУ** II *ы.* Кош-кортны куганда әйтелә торган сүз, көш. *Шулчак бәпкә саклаучы кызлар кычкырыша башлады: – Кө-өш, кө-өш! Шу-у, шу-у! Тилгән!* Р.Батулла

**ШУГА** *и.* Көзен яки язын су өстендә ага торган бозлы куерык, зим. *Көз көне, елга өстенә шуга калка башлагач, боз ныгып өлгергәнче, семьяларыгыздан аерылып яшәргә туры килә.* Ә.Маликов

**ШУГАК** *с.* Артык шома яки юеш булу сәбәпле тоткарлыксыз, шуып китә торган. *Юеш һәм шугак бүрәнәләр белән елганы чыгу бик кыен буласын белделәр, ләкин бүтән чара юк иде.* Г.Әпсәләмов. *[Агачның кабык асты] лайла белән каплагандай шугак була.* Ботаника

**ШУГАЛАК** *и.* Тимераякта шуу өчен ясалган, боз белән капланган махсус мәйдан; каток. *Ул көнне дә алар шугалакка бардылар, шактый салкын булуга карамастан, озак шудылар.* М.Маликова. *Ишегалдына ясап куйган өстәл өсте хәтле генә шугалакта, этешә-төртешә, тимераяк шуалар.* Л.Ихсанова

**ШУДЫРГЫЧ** *сөйл. и. к.* **шудырма 1.** (*1, 2 мәгъ.*). *Үлчәү площадкасына капчыкларны әрдәнәләп куюлары була, Шәмәрдән шалт та шолт. Шудыргычларны*

*әле тегеләйрәк, әле болайрак китерә дә: – Җиде центнер, әйдә ал.* Ф.Хөсни. *Ишек эчке яктан шудыргыч белән бикләнә.* М.Хәбибуллин

**ШУДЫРМА** *и.* **1.** 1) *тех.* Приборларда, механизмнарда шуып, хәрәкәт итеп йөри торган деталь. *Пешкәкнең штогы юнәлткеч яссылыклар буйлап артка һәм алга таба хәрәкәт итә торган шудырмага тоташкан.* Физика

2) *сөйл.* Ишек яки капканы бикләү өчен кулланыла торган аркылы бик. *Капканы шудырмага бикләү*

3) *диал.* Кулдан эшләнгән тимераяк. *Асты калайлы шудырма белән яңа боз өстен сыгылдыра-сыгылдыра узышулар, арганчы шар сугулар да үтеп китте.* Ш.Маннур

**2.** *с. мәгъ. к.* **шудырмалы** (*2 мәгъ.*). *Шудырма ишекле зур шкаф алдык*

**ШУДЫРМАЛЫ** *с.* 1) Шуып йөри торган. *Центроборның шудырмалы теше*

2) Тупсага урнаштырылмаган, бер як кырыйга этеп яки тартып ачыла торган (ишек, тәрәзә, тартма һ.б. тур.). *– Я, куян баласы, син нишләп төнлә йөрисең? – диде тәмәкеле кеше, вагонның шудырмалы ишеген ябып.* М.Мәһдиев

**ШУДЫРТУ** *ф. йөкл. юн. к.* **шудыру**. *Әйе, Титак Габделхак абзыйны бер өйрәтсәң ярый. Тыкрыкларындагы таудан чана шудыртмый, ашала дип беләме?* Ф.Яруллин. *Кеше күрмәгәндә генә әнисе Гөләфтар чапан кесәсенә ун тәңкә акча шудыртырга кушкан иде аңа.* Р.Рахман. *Алай гына да түгел, тора-бара ипләп кенә культура бүлегеннән дә шудырттылар үзен.* В.Нуруллин

**Шудыртып җибәрү** Уйламаганда, кинәт шудырту. *Кычкырып биргән сәламен дә алып тормыйча, өстәл астыннан кәгазь белән ялтылаш тулган иске кәрҗинне тартып чыгарды да аягы белән ишек ягына шудыртып җибәрде.* Ф.Сафин

**Шудыртып кую** Бер тапкыр шудырту

**Шудыртып тору** Әле, хәзер шудырту; һәрвакыт, даими шудырту

**ШУДЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **шуу** (*1–2 мәгъ.*). *Кызы Зәлияне чанада шудырырга да онытмый Зөлфәт.* Сабантуй

2) Авыр әйберне, күтәрмичә, шома өслектән сөйрәтеп, тартып яки этеп урыныннан күчерү. *Ул, авыр бүрәнәне бозлы ташлар өстеннән шудыра-шудыра өстерәп, Бауман урамы буенча юнәлә.* Р.Ишморат. *Вышкаларны бөтенләй сүтеп, кабат аркан белән күтәрергә дә, аударып бүрәнәләр өстеннән шудырырга да туры килгән аңарга.* Ж.Рәхимов. *Ильяс, такталар буйлап шудырып, капчыкларны әллә ни көчәнмичә генә бушатып куйды.* Р.Төхфәтуллин // Берәр нәрсәне икенче бер нәрсә өстеннән шома гына йөртеп күчерү. *Шуннан соң утырган урыннан 12–15 метрлар чамасы китәләр дә теге туң дискларны идән буйлап шудырып, чәбәйләргә каратып җибәрәләр.* З.Зәйнуллин. *– Әнә теге гәзитне шудырып кына куй әле, – диде Хәмит ---.* М.Кәбиров

3) Аякларны күтәрми, җирдән аермый гына атлау. *Фәрит, аякларын шудыра-шудыра, карт янына җитез генә килеп басты.* Д.Аппакова. *Ул аякларын шудырып кына атлый – таеп егылудан курка.* Г.Гыйльманов

4) Кулны нәрсәнең дә булса өстеннән йөртү, сыпыру. *Аннан соң әбием йөземне капшап чыкты, бер кулы белән башымнан алып аякларыма кадәр гәүдәм буйлап шудырып төшерде.* Н.Дәүли. *Ул кулларын өстәлгә җәелгән органик пыяла өстендә шудырып, алгарак елышып өстәп куйды ---.* А.Вергазов

5) Берәр нәрсәне яшерен генә, кешегә сиздерми генә йөртү, җибәрү, бирү. *«Сабирова Сөмбелгә. Сәгъдәттән», дип, эре хәрефләр белән язды һәм тәнәфестә, вакытын кулай китереп, Сөмбелнең кесәсенә шудырды да төшерде.* А.Хәлим // Нәрсәне дә булса сиздерми, белдерми генә яшерү. *Коймак тирәсендә әвәрә булып йөрүче Маһирә күрми дә калды, малай таякны ялт итеп караватастына шудырды.* А.Гыйләҗев. *Әзне оста яшерә белде Рамай, кеше-кара күрмәгәндә, теге «кыңгыраулы» касканы мәктәп почмагындагы карлыган төбенә шудырды.* Р.Низами

6) Тиз генә кабу, тиз-тиз кабып йоту, ашап бетерү. *Ул суына төшкән шашлык калҗаларын чәйнәми-нитми генә тамагына шудырды.* А.Гыйләҗев. *Эчемдәге уемны сизде диярсең: тирән генә сулыш алды да коймак калдыгын авызына шудырды ---.* Ф.Баттал. *Ике кашык шулпаны матур гына шудырдым.* Ф.Нуриев

7) *күч.* Яшереп итәк астыннан гына сатып җибәрү. *– Әллә кибеткә яңа мебельләр кайтканмы? – дип сорады Солтан. – Юк. Кайтса да аны арт яктан шудырып бетерәләр.* С.Рәфыйков

8) *күч.* Чәлдерү, урлау. *Иртән кухняда ашап утырганда, Бикташның бер телем колбасаны җиң эченә шудырганын күреп, Бәһиҗә түтәй: – Нәрсә, җитмәдемени? – дип сорады.* М.Маликова. *Малайларның --- икенчесе уенчыкларны ватып-ботарлап ташлый, өченчесе күзе төшкән бар нәрсәне кесәсенә шудыру ягын карый.* Р.Габделхакова. *Кулга эләккән алтын-көмешне, патша малы исәбенә кертмичә, изүгә генә шудырдылар.* Ф.Зариф

9) *күч.* Эштән куу, эш урыныннан чыгару. *Әлеге шул Мансур Сабирович беренче секретарь булып эшли башлаганга ел да үтмәде, Хәнәфине колхоз председателе урыныннан шудырдылар.* В.Нуруллин. *Эшемнән шудырмагайлары, шуннан шүрлим.* В.Монасыйпов

**Шудыра бару** Бер-бер артлы, булган берен шудыру. *Шикәрен шатырдатып тешли дә чөмереп торып сөтле чәй эчә, шуның белән ипи телемнәрен бик җиңел генә бер-бер артлы ашказанына шудыра бара.* Р.Рахман

**Шудыра башлау** Шудырырга тотыну. *Ул карашын --- нечкә генә зәңгәрсу һәм алсу кан тамырлары сизелеп торган кул буенча төссез дип әйтерлек төкләр җемелдәшкән беләк буенча шудыра башлады...* Ә.Гаффар

**Шудыра бирү** Бернәрсәгә игътибар итмичә шудыруын дәвам итү. *Берберенең әйберен рәхәтләнеп шудыра бир, кемнән шикләнергә дә белмәссең, барысының да ачкычлары кесәсендә!* Ф.Яруллин. *Әмма Идрисов аның сүзләрен ишетмәде дә шикелле, карандашын исемлек өстендә шудыра бирде.* Х.Камалов

**Шудыра тору** *к.* **шудырып тору**. *Ул --- мәрсин балыгының калын телемнәрен майлы ипиннәре арасына шудыра торды.* А.Гыйләҗев

**Шудыра төшү** Аз гына, бераз шудыру. *– Димәк, берегезнең дә Самат Мөбиновның эчкәнен күргәне юк? – диде тулы түгәрәк битле райком секретаре, идарә йорты эсселәнеп киткәнлектән, мамык шәлен башыннан аркасына шудыра төшеп.* В.Нуруллин. *Менә Л.Б. сул аягын алга шудыра төште.* Р.Бәдри

**Шудырып алу** Тиз генә шудыру. *[Матвей Яковлевич] калын ак мыегы өстеннән имән бармагын уңлы-суллы шудырып алды.* Г.Әпсәләмов. *Тел очын иреннәре буйлап шудырып алды да тәмле генә елмаеп куйды Самат ---.* Ф.Баттал

**Шудырып бетерү** Барысын да шудыру; ахырга кадәр шудыру. *Малайла-*

*ры, Мамай калдыклары икәнлекләрен онытмыйчамы, өстәлгә ябырылып, тиз арада аларны шудырып бетерделәр.* Ф.Яхин

**Шудырып җибәрү** Кинәт шудыру; шудырырга керешү. *Ашыкканда бәрәңге бугазга тыгылса, шудырып җибәрергә кәҗә сөте бар.* Ф.Яруллин. *Керде дә күзенә үк төшереп кигән бәрхет кепкасын арткарак шудырып җибәрде.* В.Нуриев

**Шудырып калу** Шудырырга өлгерү. *Пароход хуҗалары йөк төятүдән баш тарттылар, --- берничә сәүдә предприятиесе җилгә очты, шул арада Япония үзенең үтмәс товарларын Америка кулындагы базарларга шудырып калырга тырышты.* А.Толстой

**Шудырып карау** Тикшерү-белү максаты белән шудыру. *Хатыны берничә тапкыр шешәләрне Мәннан алдынарак шудырып карады ---.* Аманулла. *Кабул итми генә бит Иван. Дьяк аша «көтсен» дип әйттерә үзе, ә һаман чакырмый. Кылыч борынлы --- дьякның кесәсенә алтын тәңкә дә шудырып карады, файдасы гына тимәде.* М.Әмирханов

**Шудырып кую** Алдан шудыру, шудырылган хәлдә калдыру. *Һава җитмәгәндәй, камзул төймәләрен чишеп ташлады, аптыраган чырай белән түбәтәен баш артынарак шудырып куйды.* А.Әхмәтгалиева

**Шудырып тору** Һәрберсен бер-бер артлы, туктаусыз шудыру яки сөйләү моментында шудыру. *Алпавытның түбә калае көмеш төсле ак икән. --- Без Әхмәт белән, каерып алып, шыңгырдатып шудырып торабыз, астагылар алып китеп торалар.* Г.Бәширов. *Әти кыздырып тора, мин, учлап-учлап, борчакны корсакка шудырып торам.* Сөембикә

**Шудырып узу** Узып барышлый шудыру; тиз генә шудыру. *Вәзыйх Сәриянең мөлаем озынчарак йөзенә, баш артына матур итеп төйнәп куйган чәченә карашын шудырып узды ---.* Х.Камалов. *Иңенә противогаз аскан --- Миңнулла минем одеалымны акрын гына тартып, шудырып узды.* Ә.Маликов

**ШУ́ ИТҮ** *ф. к.* **жу итү**. *Кире кайтмый торган җиргә китте дигәч, йөрәгем шу-у итте.* Г.Ибраһимов

**ШУК** *с.* **1.** 1) Мәзәкчән, шаян, уенчак, кызык ясарга яратучан. *Алты җан, арадан икесе – шук малай, иртәдән кичкә кадәр бакча гөҗләп тора, турникта атыналар, шаулап балыкка баралар, гөрләп кайтып керәләр.* А.Гыйләҗев. *Ниндидер шук адәм әйткән, имеш: «Яшь кеше башта гашыйк була, аннан соң гашыйк булу объектын эзли башлый».* М.Кәбиров // Шаян, шаянлык белән тулы. *Үзе ерак та китми, түбәтәйне алдына куя да «Кил, килеп ал, бирәм инде, бирәм» дигән кебек, хәйләкәр генә карап тора. Ә күзләрендә шундый шаян, шундый шук чаткылар, йөзендә шундый вәсвәсәле елмаю!* Г.Сабитов. *Сүзгә юмор бәпчекләре, шук төсмерләр кертеп җибәрергә кирәк тапты профессор.* Т.Галиуллин

2) Әдәпсез, тәрбиясез, әрсез, тәкәллефсез. *Байбәтчәләр тук була, Үзләре бик шук була. Атадан калган маллар Ничә елда юк була.* Ш.Мөхәммәдев. *Фирая, карамый гына, ботка салынган тәлинкәне куйды да, компот салып, стакан сузды. Егет шук булып чыкты, стаканны аның кулы белән бергә тотты.* Д.Бүләков // Азгын, мут. *Карттан алдарак кына Гөлгенә, төшеп, түргә үк кереп утырып, шук күзләрен уйнатып, ит сораган иде.* А.Гыйләҗев. *Үзбәктә дәрәҗәле генә түрәнең шоферы идем мин. Моның кызы бик шук иде. Дачада егетләр белән куна иде.* Н.Гыйматдинова

3) Үткен, тапкыр, чая. *Үтә шук телле, аннары укымышлы кешеләр кебек тегесен-монысын нечкәләп тә тормый торган Фатихәттәй еш кына: «Уңган киленкәем минем!» – дип ычкындыргалый торган булды.* Г.Әпсәләмов. *Гөлчирә кечкенәдән үк шук телле чая кыз иде.* С.Сабиров

**2.** *рәв. мәгъ.* Шукланып, шаярып яки шаяртып. *– Кара, Ялтадагы кызларга гашыйк булып онытып җибәрмә, – Кави ага шук карап көлемсерәде.* И.Салахов. *– Ул инде, корешлар, хатыннарның явызлыгы борынгыдан килә, – диде, гадәтенчә шук елмаеп Рәмис.* М.Маликова

◊ **Шук куллы** Кулы тик тормый торган, кеше әйберен алырга, урларга һәвәс. *Ул – хезмәтне сөйми, ялганчы, шук куллы кеше, әйберне урламаса да, сорамыйча гына алырга ярата торган кыз.* А.Алиш. *Такта урлаучы су буеннан да китмәгән, таудан менгәч, Фәрхуллиннар чатына да борылмаган, уңга Вәли Рәхимуллаларына таба киткән. Ул, – димәк, шук куллы ир-ат...* Р.Газиз

**ШУКЛАНУ** *ф.* Шаяру, шуклыкка бирелү. *Фәнияр, малайларча шукланып: – Әйдә, хәзер әнә теге өрек агачы төбенә барабыз, – ди.* Ф.Яруллин. *Җәйге эссе көннәрдә чын көмештәй саф, боздай салкын суында юынып, кайнар тәннәребезгә хәл-егәр өстибез, шукланып, бер-беребезгә су сибешәбез, кызышабыз, егылабыз, ауныйбыз.* Г.Сабитов

**Шуклана башлау** Шукланырга тотыну. *Ишек шакып, астагы катта яшәүче апа килеп керде. Сезнең малай шуклана башлады бит әле, ди.* Г.Сабитов. *Артык шуклана башласа, әнисе дә, көчкә көлүен басып: – Азрак тынычлан инде, улым, я берәр әйберне төшереп ватарсың, әтиең ачуланыр, – дип куя.* Н.Каштанов

**Шукланып алу** Берара, бераз шуклану. *Морза ---: – И шәрәфле вә мәрхәмәтле хан, утарыңа өч ат өстәп бирәм, Алаякны гына кире кайтар, – диде. – Ә нигә саранланасың, морза, миңа калса, Алаяк биш атка тора, – дип, хан да шукланып алды.* М.Әмирханов. *Әхсән миңа туры карамый, башын аска иеп, чирәм йолка-йолка сөйләшә. Каушыйояла бугай. Әллә бер тәртипсезләнеп, шукланып алырга инде?* Р.Габделхакова

**Шукланып йөрү** Хәзер яки билгеле вакыт дәвамында шуклану. *Алай без шаян малайларның шукланып йөрергә вакытларын калдырмыйлар да диярлек, әле бер, әле икенче эшне кушып кына торалар.* А.Нәҗми. *Тыңламасаң, шукланып йөрсәң, безне башта сыек чыбык белән куркыталар, ул да үтмәсә, ыштан төбенә кычыткан салам, диләр иде.* Сөембикә

**Шукланып китү** Кинәт шуклану; шуклана башлау. *Артыграк шукланып китсәк, директорыбыз Хәсән абыйның саллы бармагы маңгайга төшә иде.* Т.Миңнуллин. *Үзе Фаязга таба ачулышикле карашлар ташлап ала иде. --- Бала артык шукланып киткәндә, ана кешенең йөзенә шундый кызыксыну чалымы чыга.* Х.Камалов

**Шукланып тору** Әле, хәзер, сөйләү моментында шуклану; һәрвакыт, еш шуклану. *Исмай Биков ике кулы белән ишекнең ике яңагына тотынып, гадәтенчә бераз шукланып торды да: – Безне дошманнар күрәлми, Без китәбез бу илдән, – дип җырлап җибәрде.* Ш.Маннур

**Шукланып яту** *сөйл. к.* **шукланып тору**. *– Шулай, шулай, Гөлчирә апа, дөрес әйтәсең, – дия-дия, пилмән ашавын дәвам итә дустым. – Карагыз аны, шукланып ятмагыз! Кеше котыртса да, сәбәп табып, борылып китегез!* Р.Сәгъди

**ШУКЛЫК** *и.* 1) Кеше характерындагы шаянлык, шук булу сыйфатлары. *Рөстәмдә балалык шуклыгы кузгалды,*

*шаярып аласы килде.* Г.Кутуй. *Шуклыгы белән башка балалардан аерыла ул. Әйтик, аякларын салындырып сиртмәле кое бурасына тотынып атына, әтисе кое өстен авыр капкач белән томаласа, малай җайлы гына куптарып ташлый.* Н.Гыйматдинова // Чаялык, җорлык. *[Мәдинә] Хәбиргә таба борылды. Шуклык, наянлык сирпегән күзләре аңа төбәлде.* Ш.Хөсәенов

2) Кызык табу, мәзәк итү өчен эшләнгән эш-гамәл, кыланыш, әйтелгән сүз. *Фәнияр Татвоенкомат ишегалдыннан ничек итеп кранга утырып чыкканын сөйләде. Илсөя дә ул вакыйганы онытмаган икән, чөнки шул шуклыгы өчен беренче мәртәбә эшендә шелтә алган.* Ф.Яруллин. *Альберт белән Ярмөхәммәтнең --- кечкенә генә шуклыгы да, артык купайтылып, арттырылып, җинаять дәрәҗәсенә күтәрелеп, һәр җыелыш саен авыз чайкауга әверелеп китте.* Р.Батулла

3) Уйнау, шаяру, ваемсызлык, гамьсезлек. *Камәретдин ун яшькә кадәр урамда яланаяк сугышып йөреп, шуклыкта мисал ителеп йөртелә башлагач, атасы аны бер кибеткә малай итеп бирде.* К.Тинчурин. *--- ир уртасы кеше малайлык шуклыкларын онытып, бар көчен --- бер максатка туплап, йөрәк ярсуын акыл көченә күчереп сабырланган төсле, елга да салмакланган.* Ф.Яруллин

3) *күч.* Шаярту. *Чигә турындагы ак тотамнар – олыгаю яки хәсрәт тамгасы түгел, табигать шуклыгы гына: көмеш чәчләр миңнәрдән үсә.* М.Маликова. *Кояш шуклыгы хикмәте генәдер. Күзләрен читкә алырга тырышты. Ә алары --- гел шул якка тартылалар. Кем соң син чакырылмаган --- адәм баласы?* Т.Галиуллин

4) *күч.* Көлү, мыскыллау, мәсхәрәләү. *Мәнә шушы җилбәзәк хатын язмыш шуклыгы белән, сугыш башлангач, әлеге «пёстатарин» иленә килеп чыга.* А.Хәсәнов

**ШУКЧЫ** *и. к.* **шамакай** (*1 мәгъ.*). *Туй. Әнә дутарчы. Әнә җырчы. Әнә зирәк сүзле шукчылар.* Казан утлары

**ШУЛ** *а.* **1.** (шуның, шуңа, шуны, шуннан, шунда; *күпл.* шулар; *тарт. форм.* шунысы, шулары) 1) Сөйләүчегә һәм тыңлаучыга таныш булган предмет, күренеш яки вакыйганы күрсәтү өчен кулланыла торган күрсәтү алмашлыгы. *Директор татарларны яратмый, диләр. Имеш, алар фән белән тирәнтен шөгыльләнә алмыйлар, тел өйрәнеп ярты гомерләре үтә. Грузинканың килүе – шуның шаукымы.* А.Гыйләҗев. *Ася аларга морфий уколы ясаган иде, шуның тәэсире булгандыр, әзрәк кенә сызлаулары басылып торадыр.* Х.Камалов

2) Алда әйтелгән фикерне җыйнау, гомумиләштерү өчен кулланыла. *[Байлар] сата, алар ашый, Бу малларны эшче ясый, Арып кайта аксый-аксый. – Шул кайната каннарымны.* Н.Исәнбәт. *Аңлатып әйтү шул: эше бик тыгыз. Партактивка җыелган ике йөздән артык кешегә илнең хәлен сөйләде.* Г.Ахунов. *Озын сүзнең кыскасы шул: Әлмәттә туганнарым бар дип, өметләнеп барып керә торган түгел.* Р.Габделхакова

3) *Әнә, мәнә* алмашлыклары янында килеп, күзгә күренеп торган яки электән таныш предметка күрсәтү, конкретлаштыру өчен кулланыла. *Елганың башы әнә шул салам түбәләре белән капланган Миләүшә авылы ягыннан башланаганга күрә, аңар Миләүшә елгасы дигәннәр.* А.Алиш. *Мәнә шул аумакай шагыйребез инде хәзер Сталинның кара җинаятьләрен аклый торган мәдхия язган дип тә ишеттем...* А.Тимергалин

**2.** *кис. мәгъ.* Җөмләдә хәбәрдән соң килеп, аны раслау, икърар итү өчен кулланыла: бит, ич, лабаса. *Әниләр күңеле даладай киң, яз кояшыдай җылы була шул.* Л.Ихсанова. *Инде җырны сәхнәдән башкарасы, халык күңеленә иңдереп, сыныйсы гына калган иде. Насыйп булмады шул, өлгермәде.* Г.Галиев

**3.** *хәб. сүз мәгъ.* Элек булганча, искечә; нәкъ үзе, үзгәрешсез. *Йөзе, күзе иреннәре шул, тик алардан элекке, басып, каплап торган караңгы тормыш тупаслыгы алынган да күзләргә акыллы нур сирпелгән ---.* Г.Ибраһимов

**4.** *мөн. сүз функ.* Иярчен ия җөмләдә *нәрсә, ни, кайсы* кебек сүзләр белән бәйләнештә килеп, ия җөмләне баш җөмләгә ияртү өчен кулланыла. *Кем эшләми, шул ашамый.* Мәкаль. *Укы никахыңны, нәрсә язган булса, шул булыр.* Г.Гыйльманов

◊ **Шул арада** Бик тиз, эш барышында ук, шундук. *Шул арада хәл-әхвәлебезне дә сорашып алды.* Ә.Еники. *Ләкин шул арада тиен икенче агачка, аннан өченчесенә, дүртенчесенә сикерде.* Г.Сабитов. **Шул килеш** ничек булса шулай, үзгәртмичә, шул рәвешчә, шул төсле, шул хәлдә. **---** *өйдә әзерләп куелган чәйләр-мәйләр шул килеш калды.* Ф.Яруллин. *Ул, --- әгәр дә күмәк көч куеп тырышсаң, җир-суларның пычранганын чистартып, әлегә кадәр чиста калганын шул килеш саклап булачагына чын күңелдән ышана иде.* М.Маликова. **Шул көе** 1) *к.* **шул килеш**. *Зиннәт өйләнмәгән иде, шул көе сугышка китеп барды да бетте.* М.Мәһдиев. *Ул хатны ачып тормадык, шул көе генә Сезгә җибәрәбез.* Н.Әхмәдиев. *Әнинең сабыны һаман шул көй сандык төбендә сакланып тора.* Фольклор практикасы; 2) Чәйне шикәр-конфетсыз, буш кына эчү турында. *[Карт шикәрне] пөхтәләп кәгазьгә төрде дә: «Малайга!» – дип, эчке кесәсенә салды, үзе, баягы кебек үк, «шул көе» белән генә чәй чөмерүен дәвам итте.* И.Гази. **Шул ук** Элеккеге, бер үк төрдәге, нәкъ үзе, нәкъ шундый ук. *Янәшә куелган чәчкечләрне ычкындырдылар, шул ук чәчкечләрне, икенче төрле көйләп, бер-бер артлы тактылар.* Н.Фәттах. *Аста рәсеме. Шул ук күзләр, шул ук беркатлы елмаю. Шул ук сабыйларча сафлык, эчкерсезлек.* М.Мәһдиев. **Шул ук вакытта** 1) Нинди дә булса эш яки вакыйганың башка бер эш яки вакыйгага параллель рәвештә, бер үк вакытта башкарылуын белдерә. *Ул кайчандыр Европаның олимпия чемпионы һәм шул ук вакытта халыкара бандит та булган.* Г.Әпсәләмов. *Хатын --- ярым йокылы бер хәрәкәт белән гәүдәсен якындагы ир ягына авыштыра төште, йөзе белән борылды һәм шул ук вакытта улын кочаклаган кулын саилчегә күчерде.* Н.Фәттах; 2) Бергә килгән төшенчә, эш-гамәл, вакыйга һ.б.ш.ның капма-каршы булуын белдерә. *Аңарда инде хатын-кызга хас оялу, тартыну хисе аз гына да калмаган иде. Ләкин шул ук вакытта аның бөтен тәне боргычлап куелган каты резинка шикелле иде.* Г.Әпсәләмов. *Аңа аптырап, шул ук вакытта куркыбрак та карап утырган ике нарасые әшнең ни турында барганын аңлап бетермәсәләр дә, нииндидер куркыныч хәл булганын сизенеп, --- кычкырып яшь коя башладылар.* Р.Сәгъди. **Шул шул** Әңгәмәдәшнең сүзен раслау, аның дөреслегенә ышануны белдерү өчен кулланыла; чыннан да, әлбәттә. *«Идел-Урал» батальоннарын төзү шактый әкренәйсә дә, туктамады бит. Аларны тик яткырмаслар инде. – Шул шул. Мөгаен, тылдагы объектларны сакларга куярлардыр.* Г.Әпсәләмов. *Мәнә син минем өемдәге җылы белән кызыксынганың бармы? Ә? Мәнә шул*

*шул. Беләсең килсә, минем ирем сугышның беренче аенда ук үлде.* М.Мәһдиев

**ШУЛАЕН ШУЛАЙ** *терк.* Алдагы җөмләдә әйтелгән фикер белән килешер-килешмәс калуны белдереп, ике җөмләне үзара терки. *Бөек талант ияләре дә шулай ук тиз, шулай ук бирелеп иҗат шатлыгына чумып язалармы икән? Шулаен шулай, ләкин бик сирәктер.* А.Кутуй. *– Анысы шулаен шулай, – дип килешәм мин, – әмма ата-ана назын мең төрле ризыклар да алыштыра алмый.* Ф.Яруллин

**ШУЛАЙ** *а.* **1.** 1) Булу дәрәҗәсен, барышын, рәвешен күрсәтү алмашлыгы. *Рәшидә, үзе аның каршысына ук килеп, --- Зөфәрнең пальто якасын төзәтергә тотынды: – Менә шулай кирәк, шулай итсәң, җылырак була!* Ә.Еники. *Әмма сине куып төшермәделәр, хатаңны аңлатырга тырыштылар. Безгә дә, шулай эшләсәк, бер дә гөнаһ булмас иде.* С.Сабиров

2) *Әнә, менә, шундый* күрсәтү алмашлыклары янында яки алмаштырып килеп, күзгә күренеп торган яки анык таныш булган эш, күренешкә, аның рәвешенә күрсәтү өчен кулланыла: шул рәвешчә. *Инде тормышлар яхшыра һәм бәхетләр тигезләнә барган саен, ул орлыклар тулысынча шытып, барлык кешеләрнең дә үзара мөнәсәбәтләре менә шулай якты, җылы булып китмәсмени?* Ә.Еники. *Минем арттан шымчылык итү, күзәтеп тору әнә шулай ачыктан-ачык дәвам итә.* З.Зәйнуллин

3) Вакыт рәвешеннән соң килеп, бер вакыйганы аңлатканда аңа хикәяләү төсмере өсти. *Кайчак шулай дәртләнеп алга барганда, аяк астындагы юк кына бернәрсәгә абынып шап итеп егыласың.* Г.Әпсәләмов. *Кайвакыт шулай да була: Хәбибнең --- хатыны балет спектакле вакытында йокымсырап китә, ә Гаҗилә җиңги урынында тынып утыра алмый, берөзлексез катнаша, сораша ---.* М.Мәһдиев

**2.** *мод. сүз мәгъ.* Алда сөйләгәннәргә нәтиҗә ясап, гомумиләштереп әйткәндә, «әйе, дөрес, чын, хак» мәгънәсен белдерә. *[Минһаҗ:] Шулай, мин бик кытыклы кеше. Тоталар да култык астыннан кытыклыйлар.* Т.Гыйззәт. *Шулай, иң рәхәт вакыт – балачак, шуңа кеше аны һаман сагына икән.* Л.Шәех

**3.** *мөн. сүз функ. Ничек, ни рәвешле* сүзләре белән бәйләнештә килеп, иярчен рәвеш җөмләне баш җөмләгә иярту өчен кулланыла. *Ярады тагын, ничек изрәп йокласа, шулай әсәрләнеп уянды да.* А.Хәсәнов. *Фәгыйлә ничек кергән булса, шулай пырылдап чыгып та китте.* А.Әхмәтгалиева

◊ **Шулай таба** Шул якка, шул юнәлештә. *Баш миенә кайнар елдырымнар каяндыр йөгереп менгәнен, канның шулай таба куылганын тойды.* Х.Камалов. *Тиздән авыл җирендә дә тормышлар арулана башларга тиеш. Эшләр шулай таба бара.* В.Нуруллин. **Шулай ук** 1) Алда әйтелгәннәрдән тыш, алда әйтелгәннәргә, алдагыга өстәп. *Барлык шушы хәлләр, шулай ук аның белән үткәрелгән әңгәмәләр Саттаровның үз эше өчен яраксыз һәм --- зарарлы кеше икәнлеген раслый.* Р.Мостафин. *Бу көнне дәүләт учреждениеләрендә, министрлыкларда, шулай ук Дәүләт Советында да махсус ике телдә, ике дәүләт телендә дә чаралар уздыру зарур.* Р.Миңнуллин; 2) Шул ук юл белән. *Караболакта шулай ук яңа туган баланы --- уты сүнгән зур мичкә кертеп ала торган булганнар, шулай итеп аңа да «кот койдырганнар».* Ф.Бәйрәмова. *Кесәңдә акча булса, бездә укымыйча да диплом алырга була. Шулай ук хәрби билетны да. Бөтен нәрсә дә сатыла бездә.* З.Мәхмүди. **Шулай бит** Фикерне хуплап, куәтләп әйтелә һәм экспрессивлык төсмере өсти. *Фәрит абый, сөенеп, шакмак кетердәтә: – Алтын-көмеш булуы тагын да яхшырак бит әле аның, шулай бит, Илгизәр туган!* Р.Сәгъди. *Берәр чәшкә чәй эчсәң, кәефең күтәрелеп китәр иде инде синең, шулай бит, абый!* Х.Ибраһим. **Шулай шул** Ризалашуны, раслауны белдереп җавап биргәндә кулланыла; әйе, әлбәттә, дөрес. *Шулай шул, кирәгеннән артыкны укырга да, белергә дә ярамый. Күп белгәннәрне элек-электән үтергәннәр.* Т.Миңнуллин. *Урлагач, иртәме-соңмы, утыртачаклар, шулаймы? Шулай шул, туган!* Р.Сәгъди

**ШУЛА́Й БУЛГАЧ** *терк.* Иярчен сәбәп җөмләне баш җөмләгә терки; әйтелгәннәрдән чыгып, нәтиҗә ясап, шуңа күрә, димәк. *Ахыр чиктә, адәм баласы үзе дә табигатьнең бер кисәкчәсе ич, шулай булгач, табигатькә чыкса, ул үзе белән күзгә-күз очраша.* А.Гыйләҗев. *Хәзерге көндә татар филологиясендә фәннәр кандидаты ватылган тиен тормый. Шулай булгач, нигә әле миңа да доктор булмаска?* М.Мәһдиев

**ШУЛАЙ БУЛСА́ ДА** *терк.* Тезмә җөмләнең җөмләләрен каршы куеп терки; ләкин, шуңа карамастан. *Ул турыда һич тә сүз кузгатырга исәбем юк иде дә, шулай булса да яшереп калдыра алмыйм инде мин синнән.* В.Нуруллин. *Яфрагы коелып бетеп, коры сабакка калган клевер печәне иде ул. Шулай булса да, атлар аны күз ачып йомганчы ашап бетерделәр.* Г.Галиев

**ШУЛА́Й ДА** *терк. к.* **шулай булса да**. *Ул алай кычкырып та әйтмәде бугай әйтүен, шулай да ата белән анага аның бу «мин» дигәне күк күкрәве сыман булып ишетелде.* Н.Фәттах. *Ел коры килде, игеннәр көйде. «Авыр булды», – дип көрсенә халык. Шулай да илнең тотрыклы хәленә ышана, еллар имин булса, җае табылыр, ди.* Ш.Галиев

**ШУЛА́Й ИТЕП** *кер. сүз* Гомумиләштереп, йомгаклап. *Хәер, повестьларны яклап чыгучылар да табылды, аеруча яшьләр арасыннан. Шулай итеп, фикерләр капма-каршы икегә аерылды ---.* Ә.Еники. *Барлык шушы күренешләрдән чыгып, нәтиҗә ясарга рөхсәт итегез: сез беркайчан да ата була алмадыгыз, соңгы вакытта аңа хокукыгызны ук югалттыгыз. Шулай итеп, без – чит кешеләр.* Ә.Баян

**ШУЛА́У** *ф. к.* **җулау**

**ШУ́ЛКАДӘР** *а.* **1.** Сан, күләм, микъдар, хәрәкәт интенсивлыгын белдергән сүзләрне алмаштырып килеп, исемнәр алдында – сыйфат, фигыль янында рәвеш функциясен үти; гаять, нык, күп. *Һади үзен шулкадәр каушар, шулкадәр югалып калыр дип һич кенә дә уйламаган иде.* М.Хәсәнов. *Мин сине шулкадәр сагындым, Гыймран.* Ш.Хөсәенов. *Акылдан язган хатын гына табар шулкадәр бала әлеге тормышта.* Э.Яһүдин

**2.** *кис. мәгъ.* Бик, үтә, артык. *Ул шулкадәр матур, шулкадәр сөйкемле, шулкадәр газиз була, чынлап әгәр, үзенә карата күңелдә әллә нинди җылы хисләр уята.* А.Хәсәнов. *Фотосурәтләре буенча шулкадәр таныш йөз!* С.Ибраһимова

**3.** *мөн. сүз функ.* 1) *Хәтта* сүзе белән бергә килеп, күләме, саны яки көче ягыннан чагыштыру функциясен үти. *Ул Дагаевның ахмаклыгыннан шулкадәр туйган иде ки, хәтта аны буып атарга да әзер иде.* Х.Ибраһим. *Ә хәзер медицина шулкадәр алга китте, хәтта җитлекмичә, 500–600 грамм авырлыкта туучы балаларны да, зәгыйфь-чирлеләрен дә дәвалап, аякларына бастыралар.* А.Галимов

2) Иярченле рәвеш җөмләдә *никадәр* сүзе белән бәйләнештә килеп, иярчен җөмләне баш җөмләгә иярту өчен

кулланыла. *Чыршының тамырлары җиргә никадәр ныграк берексә, шулкадәр тизрәк тернәкләнә.* М.Маликова. *Үзгеңнең аклыгын никадәр озак саклый алсаң, гомерең дә шулкадәр озын булыр...* А.Хәлим

**ШУ́ЛКИ** *и. сөйл. шаярт. к.* **шул көе**. *Закирә дә, Илһам әйтмешли, шулки «ашап», шулки белән «тукланып» яши.* С.Зыялы. *Әйтик, өйдә иелеп идән себергәндә яки физкультура дәресендә мостик ясаганда баш әйләнеп, күз аллары караңгыланып тора икән, ул инде чәйне күбрәк вакыт шулки белән эчкәнгә.* Л.Гайнанова

**ШУЛПА** *и. фар.* 1) Ашның сыек өлеше, ит, бәрәңге һ.б. пешкән сыеклык. *Хәл-әхвәл белешеп, күргән-белгәннәрне гәпләшеп, салкын закускаларны капкалап алганнан соң, беренче аш – токмачлы кайнар шулпа китерелә.* Ю.Әхмәтҗанов. *Тавык шулпалары, сөт ризыклары килеште Гөлкәйгә, йөзенә бераз төс керде.* Р.Габделхакова // Бәлеш эченә салу яки иткә сибү өчен симез ит һәм сөяк кайнатып махсус әзерләнгән сыеклык. *Бәлеш капкачын коры ягы белән өстәлдәге тастымалга куйды. Бәлешне болгата төшеп, кашыклап майлы шулпа сибеп, бәлеш түбәсенә өеп эчен салды.* Р.Батулла

2) Ашның үзе. *Рамил тәлинкәсен ялтыратып куйды, салфетка белән авызын сөртте. – Рәхмәт, Асия апа, мондый тәмле шулпа ашаганым юк иде, – диде.* М.Мәһдиев. *– Хәлил, Галиябануың үзеңә булсын, әниең бер тәлинкә шулпа ашатса, – дип, Бари --- Хәлилнең кабыргасына төртте.* Х.Мөдәррисова

**ШУЛПАЛАНУ** *ф.* 1) Шулпа хәленә килү, сыек массага әйләнү, сыеклану, изрәү. *Эсседән шулпаланып кайнап чыккан миемдә бер зур ачыш пешеп чыкканын сизми дә калдым, җәмәгать!* Р.Мөхетдинова. *Киң урамда таш юллар тузланып шулпаланган.* К.Кәримов

2) *күч. сөйл.* Юешләнеп ялтырау. *[Наилә] ишекне ачса, ни күрсен, бер ир кеше басып тора... Күзләре суда йөзгән май тамчылары кебек саргылтлар, шулпаланып торалар.* Х.Камалов

3) *күч.* Сыйфаты, дәрәҗәсе кимү, тулылыгы, камиллеге бетү. *Анда расланганча, бу дәреслекләр аша белем алу, урындагы саф башкорт балалары телләрен дә бозган, милли үзаңнары да шулпаланган.* К.Яуш

**Шулпалана башлау** Шулпаланырга тотыну. *Синең хакка эшләрбез, диде рәис, тегенең күзләре шулпалана башлаганын чамалап.* Х.Камалов

**Шулпаланып бетү** Тәмам, бөтенләй шулпалану. *Барыйның аты шып туктап калды: дүрт тәгәрмәченең өчесе шулпаланып беткән пычрак сулы чокырга, иплэп кенә, букәннәренә кадәр төшеп утырган.* А.Гыйләҗев. *...Фәлсәфә лекцияләреннән соң баш миләре сәер фикерләр белән тәмам шулпаланып бетә, билләһи!..* З.Хөснияр

**ШУЛПАЛАП** *рәв.* Шулпа салып, шулпа кушып, шулпалы итеп. *Борычлап, шулпалап, авызда гына тотып торырлык итеп вак бәлеш пешереп ашатсын әле үзенә.* М.Хәсәнов

**ШУЛПАЛА́У** *ф.* Шулпа хәленә китерү, сыек массага әйләндерү, сыекландыру, изрәтү. *Март ахырында ук җылы яңгырлар явып, Нократ ярындагы бөтен карны шулпалады.* К.Кәримов

**ШУЛПАЛЫ** *с.* 1) Шулпа рәвешендәге, сыек; шулпасы булган. *Башта, татар гадәте белән, шулпалы аш килде, --- кайнар ит куелды.* Ф.Бәйрәмова

2) Шулпага салып пешерелгән, шулпада пешкән. *Хак сүз, ачыккан идек, шулпалы пилмәнне дә, кролик ите белән карабодай боткасын да яратып ашадык.* С.Сабиров. *Мөслимә әби, каз ите турап, шулпалы бәрәңге куя.* Г.Сабитов

3) Махсус әзерләнгән шулпа белән ашала торган. *Кичекмәстән, нәкъ әбисе өйрәткәнчә, шулпалы, итле милли пәрәмәчкә чакырырга булыр татар халкының мөхтәрәм затын.* Т.Галиуллин. *Мин иренмим, мичкә ягып, шулпалы өчпочмак пешереп өлгертәм.* Х.Камалов // Уртасында махсус калдырылган тишек аша эченә шулпа салып пешерелгән. *Менә ул табын уртасындагы тәлинкәләрне читкәрәк этәрде дә таба белән шулпалы бәлеш китереп утыртты.* М.Маликова

4) Шулпа салынган, шулпа тутырылган. --- *ашарга карчыгы Минниса ташып тора, аңа да бер эш, ак тастымалга төрелгән шулпалы чүлмәген ике кулы белән тотып, танавын чөеп, керт-керт кенә басып килеп җитә ---.* А.Гыйләҗев. *Аннары Габдулланың кулына кайнар шулпалы чокыр тоттырды, ап-ак үрдәк боты салган шәмәхә бизәкле тәлинкәне алдына, юрган өстенә куйды.* М.Хуҗин

◊ **Шулпалы авыз** Җебегән, булдыксыз, оешмаган кеше; селәгәй авыз. *– Сволочь!.. Уз шапшагына үзе таеп егылган нәрсә. Бер шулпалы авыз иде шунда. Тар балаклы чалбар кигән булган бит әле үзе.* М.Хәсәнов. **Шулпалы ми** Аңгыра, тинтәк, акылга зәгыйфь, тиле кеше. *Шухрый шулчак Буртасның билбавына кыстырылган курайны күреп алды... – С-син, Мухрый, шулпалы ми! – диде баш вәзир, зәһәрен чакчак тыеп. – С-син туганда ук аңгыра булып туган идең, һаман акылга туя алмадың!* Р.Батулла

**ШУЛПАЛЫК** *с.* **1.** Бер шулпага җитәрлек. *Кулны сузып кына бер шулпалык балык тоттым.* Н.Әхмәдиев

**2.** *и. мәгъ.* Шулпа өчен кирәк булган нәрсә. *Хуҗа үткен пычагы белән сарыкның йомшаграк җиреннән бер шулпалыкны кисеп алып, Кердешкә тоттыра.* Ә.Еники

**ШУ́ЛТИКЛЕ** *а. к.* **шулкадәр**. *Больницада Вишневский мазе дип аталган начар исле бер дару сөртеп бәйлиләр иде. Озак вакыт аның исен иснәү Фәниярны шултикле туйдырды, исе, борынына керсә дә, күңелен болгата башлады.* Ф.Яруллин. *Авырга узганы беленгәч, шултикле шатланды, очынды.* Х.Камалов

**ШУ́ЛХӘТЛЕ** *а. к.* **шулкадәр**. *Шулхәтле байлыгың була торып, йөре инде таң тишегеннән кичкә кадәр көч түгеп!* Н.Фәттах. *Шулхәтле ышанычсыз булсаң да булырсың икән, дип, уенын-чынын бергә кушып, үпкә белдерде.* А.Әхмәтгалиева

**ШУ́ЛЧАК** *рәв.* Шул вакытта. *Ул Ларисаның иреннәренә үрелде, шулчак аның күз алдын кызыл тап томалады, ул тап машина рәвешенә керде.* М.Маликова. *Шулчак ишек артында туңган идән сайгакларының шыгырдавы ишетелде.* Н.Хәсәнов

**ШУ́ЛЧАКЛЫ** *а. к.* **шулкадәр**. *Малай: «Күпме ир туганнарым булса, шулчаклы кыз туганнарым бар», – дип җавап кайтарган.* Т.Гыйззәт. *Кеше белән --- шулчаклы шаярырга ярыймы соң?* Г.Кутуй. *Ә хәзер мин сине яратам һәм үзеңне шулхәтле дә яраттырган өчен күралмыйм. Һәм шулчаклы авыр!* Ә.Баян

**ШУ́ЛЧАКНЫ** *рәв. к.* **шулчак**. *Шулчакны өзгәләнгән сабаклар арасыннан, кем дисезме, энәләрен тырпайтып, зур гына керпе күренде.* А.Хәсәнов. *Шулчакны, аны кинәт сискәндереп, телефон шалтырый башлады.* В.Нуруллин

**ШУМАК** *и. диал.* Чанада яки чаңгыда шуу шөгыле, шуып уйнау. *Шумак шуа сабыйлар, мал сугара абыйлар;*

*Кыз-киленнәр үз эшендә, мич башында әбиләр.* М.Укмасый

**ШУНДА** *а.* **1.** 1) *Шул* алмашлыгының урын-вакыт килеше формасы; алда әйтелгән исемне алмаштырып килә һәм җөмләдә хәл функциясен үти: алдан билгеләнгән, алдан билгеле булган урында, шул җирдә, шул урында. *Каз-үрдәк бәпкәләрен, --- зур ләгәнгә су ташып, шунда диңгез ясап йөздерә идем.* Ш.Җиһангирова. *Ерактан тулы чиләкләр күтәреп кайтканда, Хурлыгаян капка төбендә утыра иде. Ярмөхәммәт тә шунда, һәр капка төбендә --- кыз-кыркын утыра.* Р.Батулла

2) Шул вакытта. *Кунаклар аның һөнәрен бик мактадылар, шулкадәрле ерак сикерә алуына таң калдылар. Чикерткә сикерүне шунда туктатты һәм кунакларны тагын үзенә тартты.* А.Алиш. *Район магазины алдында бозга таеп егылган Гөлчирә бервакыт. Шунда ишектән чыгып килүче хәрби комиссар белән райфо мөдире аны тартып торгызганнар ---.* М.Мәһдиев. *Ул шундый төш күрде: гармунда уйнапуйнап карады, көй чыгара алмады. Шунда күктән ак канатлы, үзе дә апактан киенгән бер фәрештә башта иңнәренә кунды.* Н.Әхмәдиев

3) Алда сүз булган мәсьәлә, эш, күренешнең сәбәбенә, мәгънәсенә аеруча басым ясау өчен кулланыла. *Минем укырга китмәвемнең тагын бер бик җитди сәбәбе бар, туган. Хикмәт шунда: әти бик кызу канлы, бик җиңел холыклы кеше иде безнең.* В.Нуруллин. *Комедиянең асылы шунда ки, шаян яшьләр, Юныс Хаҗиның шаһвәтле нәфесләреннән көлеп, аны яшь мөгаллимә урынына үз хатыны Галимә карчыкка «өйләндерәләр».* К.Гыйззәтов

**2.** *кис. мәгъ.* Сөйләмгә нәрсәне дә булса өнәп бетермәү, ошатмау, яратмау, игътибарсызлык төсмере өсти: инде, әле. *Лыгырдап йөри шунда үләсе карчык, мин аның андый эш белән килгәнлеген белсәм, бусагамнан аягын да атлатмаган булыр идем.* Г.Камал. *[Әзәл:] Бик кирәге бар ие. Тагын күгәреп беткән тартма эчендә черек бер китаптыр шунда.* А.Гадел

**3.** *мөн. сүз функ.* 1) Иярченле кушма җөмләдә *кайда, кая* сүзләре белән мөнәсәбәттә булып, иярчен урын җөмләне баш җөмләгә бәйләү өчен кулланыла; анда. *Андый җирдән калмый торган иде, халык кайда, ул шунда була иде.* Г.Якупова

2) Иярченле кушма җөмләдә *кайчан* сүзе белән мөнәсәбәттә булып, иярчен вакыт җөмләне баш җөмләгә бәйли

◊ **Шунда ук** Кичектермәстән, шул вакытта ук. *Язган хатлар барысы да ачып укылды, артыгын ычкындырган кешеләр шунда ук хөкем ителде ---.* Ф.Бәйрәмова. *Галиәхмәтнең тәкъдимен Мөнирә шунда ук кабул итте.* Ф.Яхин

**ШУНДА ДА** *терк.* Кире җөмләне ияртү өчен кулланыла: шулай булса да, шулай булуга карамастан, шуңа да карамастан. *Кеше гомере. Дәрьяның бер тамчысы. Әмма шунда да ул мәңге яшәрдәй булып кылана ---.* Г.Әпсәләмов. *– Минем өйдә бүтән эзегез булмасын! – дип акырган чагымда да сабырлыгын җуймады ул. Шунда да иплән кенә җайларга-көйләргә тырышып карады мине ---.* В.Нуруллин

**ШУНДАЕН** *а. диал. к.* **шундый 1.** (*3 мәгъ.*). *Ир исемен йөртә икән, шундаен дан хатынга өйләнергә җөрьәт иткән икән, Нәҗибең кайгыртсын!* А.Гыйләҗев. *Җария шундаен сыгылмалы сынлы, зифа буйлы иде ки, озын муенындагы алсу шарф сүтелеп, кош булып очып китәр сыман.* М.Хәбибуллин

**ШУНДУК** *рәв. сөйл. к.* **шунда ук**. *Хатынын күрүгә, ир шундук коелып төште, телсез калды.* Х.Ибраһим. *Мин эшнең кай тарафларга киткәнен шундук аңлап алам.* Р.Сәгъди

**ШУ́НДЫЙ** *а.* **1.** 1) Вакыйга, күренеш, предмет яки затка яисә аларның берәр төрле сыйфатына, үзенчәлегенә ишарәли торган күрсәтү алмашлыгы; андый. *Алар шундый тәмле ислемайны кайдан табалар икән?* Г.Камал. *Тормышта кеше барыбер кайчан да булса язмышы белән күзгә-күз кала. Менә минем шундый көнем җитте.* Ф.Яруллин

2) Алда сүз барган нәрсә кебек; шуңа охшаган. *Үз атасы булмагач, аны инде элеккечә яклаучылар табылмас. Бер анасының гына яклавы аны үги атаның кырын күзеннән, яманлыгыннан саклап кала алырмы? Бикәнең күңелен менә шундый уйлар борчыды.* Н.Фәттах. *– Акыллы олан, – диде Андрей кенәз һәм сикереп урыныннан торды да Гали оланны күтәреп алды. – Шундый оныгың булса икән, хан!* М.Хәбибуллин

3) Бик, үтә, артык, гадәттән тыш, чиктән ашкан, искиткеч, искитмәле, шулкадәр. *Ул – бөтенләй башка туташ. Беләсезме, ул шундый чибәр, шундый ягымлы, шундый... Күзләреннән ниндидер илаһи нур сирпелә.* Г.Каюмов. *Ул да булачак иде бит слётта! Шундый матур, шундый зирәк кызның әлеге тантанага килми калуы мөмкин түгел!* Ялкын

**2.** *мөн. функ.* 1) Иярченле аергыч җөмләдә *нинди* сүзе белән бәйләнештә килеп, иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйли. *Шул сәгатьне беренче таккан-да, әни: – Улым, сәгатеңне бик саклап тага күр. Беренче таккан сәгатең нинди булса, хатының да шундый булыр, – дип кисәтте.* А.Хәсәнов. *Халкы нинди булса, хөкүмәте шундый, диләр.* А.Тимергалин

2) Баш җөмләнең аергычы булып, *андый, хәтта, әйтерсең лә* кебек сүзләр белән бергә аныклагыч җөмләне баш җөмләгә бәйли. *Бала шундый акыллы икән, хәтта тирә-яктагы барлык халык шаккаткан, ди.* Әкият. *Ә тирә-якта шундый тынлык, шундый тынычлык, әйтерсең табигать бик каты тартыштан соң арыган да хәзер, әкрен генә сулыш алып, хәл җыя.* Г.Әпсәләмов

3) Баш җөмләдә аергыч булып килеп, иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйли. *Бүлмәгә атылып кергән участковый шундый күренешкә тап булды: кызыл җирән чәчле, таза бәдәнле ир күлмәкләре ертылган, изүләре ачык, тулы аяклары ялангач хатынның күкрәгенә тезен куйган да битен чәбәкли, башын төя ---.* Т.Галиуллин. *Яшүсмернең шундый ягын табыгыз: үзендәге үзгәрешне үзе дә тоярдай булсын.* Н.Әлмиева

**ШУНЛЫК** *а.* Шуңа җитәрлек, шуңа кирәк кадәр. *Бакчада – аулак. Борын башына – берәр ярты. Я, ничек? --- Шунлык кына рәтегез бардыр ич?* Ә.Баян. *Квартирны да үзеңдә калдыр, баланы да бирмә! Шунлык та үткенлегең юкмыни?* М.Маликова

**ШУНЛЫКТАН** *терк.* Иярченле кушма җөмләдә иярчен сәбәп җөмләне алмаштыра һәм баш җөмләгә бәйли. *Шушы Сидоров ротага килүе белән, үзенең үтә формалист, шунлыктан аеруча дорфа икәнлеген күрсәтеп өлгерде.* Ә.Еники. *--- тора-бара кыз бала үзенең ятимлеген сизә башлаган. Шунлыктан ул шикчел, астыртын булып үскән.* Н.Фәттах

**ШУННАН** *а.* **1.** *Шул* алмашлыгының чыгыш килеше формасы 1) Алда әйтелгән кем яки нәрсәдән, шуңардан. *Тамагына да рәтләп ашамады: каткан ипи кисәге белән бер чокыр су – аның көнлек ризыгы күбесенчә шуннан тора иде.* М.Галәү. *Кешеләр үзләренә*

*бирелгән гомерне иминлектә, үзара аңлашып, сөеп-сөелеп үткәрергә тиешләр. Пьесаның асыл мәгънәсе нәкъ әнә шуннан гыйбарәт.* Х.Миңнегулов

2) Шул урыннан, шул җирдән. – *Мин бит агач башына гына менгән идем. Шуннан ялгыш кына егылып төштем, – диде елан.* А.Алиш. *Иң элек дүртенче трамвай белән Суконный бистәсен узып, аның ахыргы тукталышына кадәр бардык та, шуннан җәяү киттек.* Ф.Галиев

3) Шул вакыйгадан, эштән, хәлдән соң, берникадәр вакыт үткәч, нәрсәдер булып үткәч, шул вакыттан соң, аның соңында. *Минем Уфада булуым берике көн генә дәвам итәргә тиеш. Тагын бер-ике көн – туган-үскән җирләрне карап узу. Шуннан инде туп-туры Казанга!* Н.Нәҗми. *Кечкенә чагында капка башыннан егылып төшеп башын бәргән иде, шуннан рәтләнеп китә алмады, бичара.* Аманулла

4) Ахырда, ахыр чиктә. *Хатын әйтә: патшадан гафу сорасын, бәлки, кичәр, ди. Мин әйтәм: ярамый, дим. Әнә Шакир әйтә: сораса ни була, сорый бирсен, ди. Менә Җиһангир иптәш тә, ярамый, ди. Шуннан талашабыз.* Г.Ибраһимов

5) *Башта, элек, иң беренче* сүзләре белән килеп, эш яки вакыйганың эзлекле барышын белдерә; аннары. *Элек бабай утын ярды, шуннан мич ягып җибәрде.* Сөембикә

6) Алда белдерелгән эш-хәл соңыннан белдерелгән эш-хәлнең сәбәбе булуына ишарәли; шуңа күрә, шул сәбәптән. *Ул, Карачай күлен күмгәндә, бик көчле радиация алган һәм чак кына үлемнән калган икән, сукыраюы да шуннан икән.* Ф.Бәйрәмова. *Бездә бит яһүдләрдәге шикелле тәрбия системасы юк, җитешсезлекләр дә шуннан килә.* С.Ибраһимова

**2.** *ы. мәгъ.* Сорау, шөбһәләнү, ирония һ.б.ш. төсмерләр белдерә торган сөйләүченең хикәяләвен ашыктыру өчен кулланыла: я, тагын, дәвам ит. – *Укыдык. Без укыдык, – диешteләр кызлары. Йөзенә кызыксыну билгесе чыгарып, Газинур да: – Шуннан, шуннан? – дип куйды. – Ни-нәрсә дип язган Джеймс әфәнде?* А.Хәсәнов. – *Кызлар белән йөрмичә, аларга өйләнеп булмый, дисең. Менә. Кызлар яныннан кайтып киләм. – Шуннан? – Нәрсә – шуннан? – Кем соң ул?* Г.Гыйльманов

**3.** *мөн. сүз функ.* Иярченле урын җөмләдә *кая, каян, кайдан* сүзләре белән мөнәсәбәткә кереп, иярчен җөмләне баш җөмләгә терки. *Тәгәрмәчнең алды каян, арты да шуннан.* Мәкаль. – *Аллага шөкер, хәтерем дә яхшы, авылдагы бар чордашларымны исемләп беләм, әйберне кая куйсам, шуннан алам, – ди ул.* Якты юл

◊ **Шуннан соң** Шул моменттан алып, шул урыннан башлап. *Шуннан соң тоттым да --- ат-арбалар төяп йөртә торган иске «Волгарь» паромына утырып, үзебезнең Югары Осланга чыгып киттем.* Ә.Еники. *Миңнулла шуннан соң берничек тә, беркайчан да шәһәрдән килгән концерт, спектакльләргә йөрмәде, телевизордан берәр спектакль тапшырсалар, тәмәкесен алып, ишегалдына чыгып утыра торган булды ---.* М.Мәһдиев. *Утташ кам җиңелде, тик шуннан соң ул үзенең киявенә каршы эшне уйлабрак, астыртынрак эшли башлады.* Н.Фәттах

**ШУ́НЧА** *а. иск. к.* **шулкадәр**. *Дөнья йөзендә күпме әдип, шагыйрь яки композитор булса, шунча ук шәхси үзенчәлек, шунча ук язу алымы һәм дөньяга караш яшәп килә.* Г.Бәширов. *Афзал Шамов моны үзе дә шулай аңлагандырмы --- анысын мин белмим ---. Әмма мин үзем шунча еллардан бирле үземне шуның өчен сүгеп киләм, моңа күңелем рәнҗи.* Г.Әпсәләмов

**ШУНЫ** *а.* **1.** *Шул* алмашлыгының төшем килеш формасы, алда әйтелгән предмет яки күренеш атамасын алмаштырып килә: шул кешене яки әйберне. *Абзар алдында гына бер чуен чүлмәктә Сарбайга дип салып куелган итле аш бар икән, шуны ялтыратырга тотынган ул.* Ф.Яруллин. *Патшалыгымда нинди үзгәрешләр бар икән, хәзер шуны карарга юлга чыгам.* Р.Батулла

**2.** *мөн. сүз функ.* 1) Иярчен тәмамлык җөмләдәге *кем, нәрсә, ни* сүзләре белән мөнәсәбәткә кереп, аны баш җөмләгә бәйләү өчен кулланыла. *Кулым эштән курыкмый. Күзем яхшы күрә. Ни кушсалар, шуны эшлим.* Н.Фәттах. *Эшләпәле ир --- Нәҗибә апаның тавышын ишеткән икән. – Үземнең мал, нәрсә телим – шуны эшлим! – дип кенә җибәрде.* Д.Бүләков

2) Баш җөмләнең тәмамлыгы буларак, иярчен аныклагыч җөмләне баш җөмләгә бәйләү өчен кулланыла. *Тик шуны бел: син миңа хатын-кыз буларак түгел, фәрештә буларак кирәк.* Ф.Садриев. *Мин үзебезнең тәҗрибәдән чыгып шуны әйтә алам: кучмә утырышлар алар бермә-бер нәтиҗәлерәк.* Р.Миңнуллин

**ШУНЫҢ** *а.* **1.** *Шул* алмашлыгының иялек килеш формасы; алда әйтелгән предмет яисә күренеш атамасын, шулай ук җөмләне алмаштырып килә. *Мин тышта йөргәндә, Муллакаев Мәгъсүм дигән малай мылтыкны алган да шуның белән башка укучыларны куркытып уйный, ди.* Ә.Баян

**2.** *мөн. сүз функ.* Баш җөмләнең тәмамлыгы буларак, иярчен аныклагыч җөмләне баш җөмләгә бәйләү өчен кулланыла. *Чире борылып кайткандыр Нәҗипнең, шуның кәсафәтедер!* А.Гыйләҗев

◊ **Шуның аркасында** Шул сәбәпле, шул җирлектә, шунлыктан, шуңа күрә. *Ул дөреслектә шул ук Григорий аркасында дошман тозагына эләгүен һәм хәзер тагы шуның аркасында авыр фаҗигалы көннәр кичерәчәген белмәде.* А.Расих. *Шәрәфнең ачуы чыкты: – Мин әйткәнгә язмыйсың инде, диде. Шуның аркасында берничә көн үпкәләшеп йөрдек.* Л.Ихсанова. **Шуның белән бергә** *к.* **шул ук вакытта**. *Минем гомерем шактый ямьсез, шактый караңгы, шуның белән бергә кызык кына үткән булганга, яза башлагач, исемдә калганнарның һәммәсен язасым килде.* Г.Тукай. *Үзән елганың киң ятуларында су белән рәхәтләнгәннән соң, һәммәсе яңарып, көчләнеп, шуның белән бергә ачыгып, арбалар янына килделәр.* Г.Ибраһимов. **Шуның өстенә** Санап үткән эш, билгеләргә тагын да өстәп; җитмәсә. *Зур тираж белән басылганлыктан, ул халкыбызның 150 әкиятен йөзләрчә мең укучыга, шул исәптән рус теле аша башка бик күп милләт укучыларына да барып иреште. Шуның өстенә күп халыкларның фольклор галимнәре өчен дә мөһим чыганак булды.* Р.Миңнуллин. *Сабиров --- һәр артист белән аерым шөгыльләнеп, аларның музыкаль сәләтләрен ачуда ярдәмен күрсәтә. Шуның өстенә, баянда уйнау белән генә чикләнмичә, аны театрның музыка бүлеге мөдире итеп куялар ---.* Д.Гыймранова. **Шуның өчен** *к.* **шуңа 2.** *Кешене тышкы дөнья белән бәйли бит ул тәрәзә... Шуның өчен зур булсыннар алар.* А.Гыйләҗев. *Аннан килеп, шәһәрне төзү өчен акча кирәк, шуның өчен якын араларда совхозга ондатралар кайтартабыз.* А.Вергазов. **Шуның белән вәссәлам** «Шуның белән эш тә, сүз дә бетә, мәсьәлә хәл ителә» дигән мәгънәдә. *Малларны ашатасың, кар көрисең, утын кертеп мич ягасың, су ташый-*

*сың, фермага эшкә барасың, кер юып ашарга пешерәсең --- дә шуның белән вәссәлам, теләсәң ни эшлә, туйганчы ял ит.* З.Мурсиев. *Шул бюро-мазар буласы булса, бераз кәгазь кыштырдатасы да, аннан берәрсен кандидат итеп яки партиягә алсалар, тиешле документларны әзерлисе дә шуның белән вәссәлам.* Н.Көбәш

**ШУНЫСЫ** *а.* **1.** *Шул* алмашлыгы формасы: алда әйтелгән сүзне аерып алу, аерып күрсәтү өчен кулланыла. *Миңа шунысын бирегез! Миңа шунысы гына калган*

**2.** *мөн. сүз функ.* Баш җөмләнең тәмамлыгы буларак, иярчен аныклагыч җөмләне баш җөмләгә бәйләү өчен кулланыла. *Леспромхозның шунысы ярый: күпме киссә, шуның кадәр утыртып китә.* М.Мәһдиев. *Наданның шунысы куркыныч: ул һәрнәрсәне белә, ни эшкә тотынсам, шуны булдырып чыгам, дип уйлый, бахыр.* Ф.Сафин

**ШУҢА** *а.* **1.** 1) *Шул* алмашлыгының юнәлеш килеше формасы, алда әйтелгән төшенчәне яки җөмләне алмаштырып килә: шуңарга, шул кешегә яки әйбергә, шул фикергә. *Шуңа төрөп куй. Шуңа тоз өстә*

2) Җөмләнең тәмамлык кисәге буларак килеп, үзен ачыклауны сорый. *Бүгенге конференциябез материаллары да шуңа, игелекле максатка хезмәт итәр, дип уйлыйм.* Р.Заһидуллин

**2.** *терк. мәгъ.* Шул сәбәпле, шунлыктан, шуның өчен, менә ни өчен. *Миңнуллаларның үз авыллары тирәсе тип-тигез, рәхәтләнеп чана-чаңгы шуарлык бер генә тау да юк. Шуңа тау күргән саен, күңеле җилкенеп куя аның!* Ф.Нуруллин. *Бер җайга гына, сөт сепараторы кебек гөрелдәп кенә чыга әбиеменең тавышы, шуңа, ахры, изрәп йоклап киткәнмен.* Г.Якупова

**3.** *мөн. сүз функ.* Иярченле тәмамлык җөмләдәге *кем, нәрсә, ни* сүзләре белән мөнәсәбәткә кереп, иярчен тәмамлык җөмләне баш җөмләгә ияртү өчен кулланыла. *Мактау шуңа, кемнәр --- Яшен кебек удар ясый фашистларга.* Ә.Ерикәй. *Ни кушсалар, шуңа йөгердем.* Ф.Садриев. *Инде барысы да Иван патшаның бу котырган уйлары белән килешкәннәр, ул нәрсә әйтсә, шуңа ризалар иде.* Ф.Бәйрәмова

◊ **Шуңа калса** Әгәр эш алайга китсә, аңа терәлсә; кирәк булса. *– Аңламый Тукаев, – диде Камил, зарланып. – Мин зәррә кадәр дә үзем өчен хафаланмыйм. Мин инде, эш шуңа калса, җырлап та тамагымны туйдыра алам.* А.Расих. **Шуңа китсә** *к.* **шуңа калса**. *Әгәр эшләр шуңа китсә, качып китәргә генә кала, ләкин шул мизгелдә ишектә сакчы күренде.* Р.Мирхәйдәров. **Шуңа күрә** *к.* **шуңа 2.** *Бу уй Назимовка шулхәтле авыр тәэсир ясады, гүя ул үзен ятим калган кебек хис итте, шуңа күрә хәзер штаб булып әверелгән 1 нче баракка бармыйча, үз барагына кайтты да өстәлгә капланды.* Г.Әпсәләмов. *Без – көтеп алынганнар, шуңа күрә үзебезгә карата һәрдаим җылылык сизеп тордык.* Ю.Сафиуллин

**ШУҢА́ КАРАМАСТАН** *терк.* Кире җөмләне баш җөмләгә бәйли: шулай булса да. *Ул миңа бер комплимент та әйтмәде, --- ләкин шуңа карамастан мин кыз йөрәгем белән аңа бик ошавымны, дөресрәге, торган саен ошый баруымны сиздем.* Ә.Еники. *Кыргый җанварга кабат унлап ук кадалды. Шуңа карамастан ул якынайганнан-якыная иде.* Р.Сәгъди.

**ШУҢАР** *а. к.* **шуңа 1.** *Айга бер театрга барсак, атнасына бер кино карасак, шуңар да канәгать булабыз.* Л.Ихсанова. *Кичә үпкәләшкән идек, шуңар авызын турсайткандыр кортка дип, ишекне яптым ---.* Н.Гыйматдинова

**ШУҢАРГА** *а. сөйл. к.* **шуңа**. *Мин үзем 23 нче елларда бик тәти, бик матур, каһәр суккан бер кызны очратып, шуңарга өйләнгән идем.* Һ.Такташ. *Шкафның бер аягы гына әзрәк какшаган иде, аягын ныгытып бирдем. Гарифулла кордаш бигрәк кече күңелле кеше инде, шуңарга да сөенеп калды.* Ф.Яруллин

**ШУҢА́РЧЫ** *рәв. к.* **шуңача**. *Гафифә апа сугыш алдыннан гына аңа киявгә чыкты, яратып чыкты. Шуңарчы бер генә егеткә дә тәненең бер генә урынына да кагылырга рөхсәт итмәде.* М.Мәһдиев. --- *очкычтан аерылгач та, «бер, ике, өч», дип, ашыкмыйча гына алтыгача саныйсың, аннары баш өстеңә күтәрелеп карыйсың. Әгәр дә шуңарчы парашютың ачылмаган булса, күкрәгеңдәге каешка беркетелгән бөҗраны тартып аласың ---.* М.Маликова

**ШУҢА́ЧА** *рәв.* Шул вакытка чаклы, шуңа кадәр. *Нәрсә бу – көнләшүме әллә? Уелданов, йөрәген тотып, түшәгеннән торып утырды. Шуңача үзенең бәхете камил булуга ышанып яшәгән Хәләф Борһанович... көнләшәме?* Т.Гарипова. *Эшең әзер булу белән, мин туфан сулары күтәрәчәкмен, шуңача хатының, бала-чагаң белән көймәгә кереп кал.* Ә.Әминев

**ШУҢЫНЧЫ** *рәв. сөйл. к.* **шуңача**. *– Электротехник училищега әзерлек курслары октябрьдә ачыла икән, шуңынчы түз инде, – дип ымсындырып һәм юатып торды әтисе.* М.Маликова. *Озакламый караңгы төшәр, шуңынчы әнә теге йорттан бүлмәләр алып, урнашып куегыз.* М.Кәбиров

**ШУПЫРДАТУ** *ф. сөйл. к.* **шаптырдату**. *Бу уйлардан тизрәк арынырга теләгәндәй, чәен шупырдатып эчте дә кружкасын читкәрәк этеп куйды.* Х.Камалов. --- *Рәфис үрмә гөлле стена артында гына таза бәдәнле тракторчы егетләрнең булыр-булмас итле ашны шупырдатып эчүен ишетеп торгандай булды.* А.Вергазов

**ШУПЫРДА́У** *ф. к.* **шапырдау**. *Моннан соң күргән бер җирдә алай кинәттән генә суга шупырдап кереп китмәскә, саграк булырга киңәш иткәннәрдер инде.* А.Хәсәнов. *Кар өстенә ат түгел, кеше генә басса да, аяк, шупырдап, сулы карга бата.* З.Зәйнуллин

**ШУПЫРУ** *ф. сөйл. к.* **шопыру**. *Сәрия апасының чат токмач ашларын иртәсен дә, кичен дә берәр чуен шупырып, апаларының прәннек-печеньеләре белән генә сыйланып, Чатан берәр айдан танымаслык булып матурайды.* А.Хәсәнов // Гомумән ашау. *Шупырырга бәрәңге шулпасы булмасын да, өй борынча тәмәке сасытып, аракы эчеп йөрсен имеш, адәм имгәге!* Ф.Бурнаш

**ШУР** *и. фар.* 1) *иск.* Тоз

2) *к.* **шүр**. *Балыклар тоз шурыннан агарып катсалар да, кат-кат кайнатып чыгарсаң, теш арасына кыстырырга ярарлык иде.* Г.Минский

**ШУРА** *и. гар.* Хакимиятне гамәлгә ашыра торган сайлаулы, вәкаләтле орган; совет. *Шуннан соң, 1918 елның язында, штат урынына «Татар-башкорт шуралар җөмһүрияте»н булдыру идеясе туа.* Ә.Еники. *Чакырып кына калмаганнар, үзләренең депутатлары аркылы Дәүләт Шурасына канун проекты да тәкъдим иткәннәр.* А.Тимергалин. *Шушы ач әрвах ниндидер юл белән большевиклар фиркасына үтеп кергән дә Күчәрбайда авыл шурасы рәисе булып алган менә.* В.Имамов

**ШУРПА** *и. фар.* Сарык итеннән әзерләнгән майлы шулпага яшелчәләр яки дөге салып пешерелгән көнчыгыш ашы. *Ашау яхшы, мондагы ашханәләрдән зарлану гөнаһ булыр иде, яшелчә,*

*җиләк-җимеш күп. Үзбәк кухнясына өстенлек бирәм – пылау, шурпа, шашлык, манты.* Р.Мирхәйдәров. *Бәрәнне суйдык, шашлык әзерләдек, шурпа пешердек.* Казан утлары

**ШУРФ** *и. нем. махс.* Казылма байлыклар эзләү, шартлату һ.б.ш. эшләр алып бару өчен вертикаль яисә авыш итеп казылган артык тирән булмаган кое. *Безнең алдыбызда, исемсез геройларның фәкать берсе. Ә күпме алар менә шушы коточкыч коеда, күпме алар җан кыю машиналарында, шахта шурфларында, Әбиләр ярында газиз башларын җуйдылар!* Г.Әпсәләмов. *Әлеге стратегик әһәмияткә ия тау токымын кәйләләр белән чабарга керешкәнче, ишәсе стенада метр-метр ярымнар эчкә шурфлар тишәләр.* А.Хәсәнов

**ШУТ** *и. рус* 1) Русларда патша сараенда яисә бай йортында, кунак һәм хуҗаларның күңелләрен күтәрү өчен, төрле кыланышлар күрсәтеп, кызыклар, мәзәкләр сөйләүче кеше. *Гюгоның «Көлә торган кеше» романында, шутлар, балаганчылар итеп үстерү өчен, сабый балаларны махсус гарипләндерүчеләр – компрачикослар турында укып җан өшегәне бар иде.* М.Мәһдиев

2) Балаганда, борынгы комедияләрдә комик персонаж; шамакай. *Шәмсүн катлаулы тормыш сәхнәсендә җитди һәм кырыс геройларны уйнарга гадәтләнгән, инде бу аның холкына күчә язган; хәзергесе – шут булып кыланырга азаплануы – беренчесе, шуңа күрә аның өчен ят иде.* А.Вергазов

**ШУУ** *ф.* 1) Чанада, чаңгыда таудан кар өстеннән ышкылып бару, үтү, тимераякта боз өстеннән этелеп, ышкылып йөрү; таю. *Тормыш зарарсыз иде, өс бөтен, тамак тук, тау шуарга чана бар, әнинең сеңлесе йомшак бәти йоныннан бәйләп, өстеннән киндер белән баш сапкан бияләй бик җылы.* Г.Камал. *Иртәгә китәләр инде, Казанда аяздыр, каникул беткәнче, тимераякта шуып, чаңгыда йөреп рәхәтләнергә өлгерер әле Назыйм.* М.Хуҗин

2) Нәрсәнеңдер өслеге шома булу сәбәпле, эләктерүе, тотуы кыен булу. *Кулыма бер балык кергән иде, шуып чыкты, качты.* К.Насыйри. *Шома чәченнән әледән-әле шуып төшкән күксел ефәк шарфын төзәткәләп, табындагы --- җимеш тулы савытларга күз йөгерткәләп хәрәкәтсез утырганга, вакыт бик әкрен узды ---.* М.Маликова

3) Нәрсәдер өстеннән тоткарлыксыз, шома гына һәм бик тиз хәрәкәт итү

4) *к.* **шуышу**. *Бөек крепостьларның тишекләреннән авызлары безгә каратып куелган зур тупларның өзлексез яудырган утларына каршы боз өстеннән күкрәк белән шуып бара идек...* Г.Ибраһимов. *Ханның җәяүләнгәнен күргәч тә, бер олан, шуып барган уңайдан тезенә төшеп, хан аягы астына кадәр килеп, маңгаен хан итегенең йөзенә орды.* Р.Батулла

5) *куч. гади с.* Кемнән яки нәрсәдән котылу, ычкыну. *Кызны бу кыен хәлдән тизрәк коткару өчен, ишкәкләрне каерып-каерып сала башладым. Көймә җитез шуып алга китте.* Ш.Маннур. *Егет, исен җыеп, тиз генә аның кочагыннан шуып чыкты да, алпантилпән атлап, ишеккә таба китте.* З.Хөснияр // Беркемгә дә әйтмичә, тиз генә, ашыгыч рәвештә китеп бару, шыпырт кына китү, качу, шылу. *Галләм дә каласына шома гына шугандыр инде.* М.Фәйзи. *Алар мунчага керер-кермәстән, Бәдигыльҗамал түти дә, Маһипәрваз апа да төлкедәй елгырлык белән келәткә шудылар.* Р.Батулла

◊ **Шуып үтү** Эшнең, мәсьәләнең асылына төшенмичә, аннан-моннан гына эшләү; өстән-өстән генә башкару; басым ясамау, игътибар җәлеп итмәү. *[Докладымны] хәзерләдем түгел, уйладым. Кайсы сүз белән ничек итеп башларга, кайсы җиргә җиткәч, кычкырыбрак җибәрергә, кай урыныннан шуыбрак үтәргә.* Ф.Хөсни

**Шуа төшү** Бераз шуу. *Юрган астыннан югары төшкән йокы пәрдәсе дә шуа төшеп, Гафур аннары караваттан җәһәт кенә кузгалып, аякларына басты.* Ә.Баян

**Шуып алу** Аз гына, бераз шуу, кыска вакыт эчендә шуу. *Алар белән бергәләп чанада да шуып алды.* Якты юл

**Шуып калу** Шуарга өлгерү, вакытында шуу. *Малайлар, җыеныгыз! Безгә иртә белән шуып калырга да төшке ашка кайтып өлгерергә кирәк.* Сөембикә. *Кыш көне күпләр чаңгыда, чанада, тимераякта шуып калырга ашыга.* Шәһри Казан

**Шуып карау** Шуу юлы белән сынау. *Кәрим дә бер генә мәртәбә шуып карарга булды.* Ф.Садриев. *Кеше күрмәгәндә генә шул таудан шуып карыйсы килә!* Ш.Галиев

**Шуып тору** Әле, хәзерге вакытта шуу; һәрвакыт, даими рәвештә шуу. *Күбек төсле күпереп торган кардан Шуып торды безнең чанабыз.* М.Җәлил. *Өшемәс өчен, көн буе Шул таудан шуып торам.* Г.Гыйльманов

**ШУ́ХЫР-МУХЫР** *и. нем. гади с. к.* **шахыр-махыр**. *Надан булса да, ул чакта да халык ахмак булмый. Сизәләр моның шухыр-мухыр белән шөгыльләнгәнен.* В.Нуруллин

◊ **Шухыр-мухыр китерү** *к.* **шахыр-махыр китерү**. *Тормышка җиңелчәрәк баккан яшьрәк галимнәр бу эшләрне шухыр-мухыр китергәлиләр.* Д.Хисметдин. *Алар шухыр-мухыр китереп алынган 5 миллионлык иномаркаларда йөри, ләкин Апас халкына ипи пешерерлек итеп ипи комбинатын эшләтү хәлләреннән килми.* Безнең гәҗит. **Шухыр-мухыр кору** *к.* **шахыр-махыр китерү**. **Шухыр-мухыр ясау** Интрига ясау, җәнҗал чыгару

**ШУШЫ** *а.* 1) Якында булган, күренеп торган нәрсәгә, конкрет бер нәрсәгә яки кешегә күрсәтү өчен кулланыла. *Хикмәт шунда: әле күптән түгел генә өяз башкарма комитеты хезмәткәренең туган көнендә бергә утырганда, менә шушы кеше, миңа ярамый, егетләр, дип, грамм да эчмәгән иде.* В.Нуруллин. *Менә шушы шигырьләрне карап чык әле.* М.Шабаев

2) Алда әйтелгәнне йомгаклап гомумиләштерү, игътибарны шуңа юнәлтү өчен кулланыла. *Шул Рур өлкәсен алсагыз, Басыйр абзый әйткәнче диярсез, сугыш тизрәк бетәр. Шушы нәрсәне исегездән чыгармагыз, егетләр!* З.Зәйнуллин. *Халык күңеленә ятарлык җыр иҗат иткәнбез икән, бу бәхет, шатлык түгелмени? Шушы шатлык безгә картаерга ирек бирми.* Р.Юныс

**ШУШЫЛАЙ** *а.* Эш-гамәлнең үтәлеш рәвешен конкрет, аерыбрак күрсәтү өчен кулланыла; шушы рәвешле, менә шулай. *Бүләк яулыгыңның читләрен менә шушылай чыгарыбрак калдырып, мамык шәленңе ура да — әйдә, киттек!* М.Хуҗин. *Кем генә айга багышлап җыр чыгармаган, ялгыз айга карап моңаймаган, кемнәрдер ялгызлыктан шушылай айга бакканнардыр.* Н.Хәсәнов

**ШУШЫЛДА́У** I *ф. к.* **пышылдау**. *Бер читтә яшь кызлар шушылдыйлар*

**ШУШЫЛДА́У** II *и.* Ишетелер-ишетелмәс пышылдаган тавыш. *Латыйфә, бар көчен җыеп: – Гаеп миндә, гөнаһсызларны җәзаламагыз! – диде. Халык арасында шушылдау башланды.* Шура

**ШУШЫНДА** *а.* Якында булган аерым, конкрет бер урынны күрсәтү өчен

кулланыла; менә шунда, шушы урында, шушы җирдә, монда. *Мин бит һаман шушында, беркая да киткәнем юк.* Ә.Еники. *Әхмәт Рәшитов турында сүзне шушында тәмамларга да мөмкин булыр иде.* Ф.Яруллин. *Менә Шайтан елгасының Сулук суына койган тамагы, язын шушында Птенцовлар, таш өеп, яр читен ныгытканнар иде.* С.Шәрипов // Алда әйтелгән сүз яки фикерне алмаштырып, гомумиләштереп килә. *Асылда, бөтен драманың төенләнеше шушында бит.* М.Җәлил

**ШУШЫ́НДЫЙ** *а.* Сыйфатны конкрет, аерыбрак күрсәтү өчен кулланыла; менә шундый. *Шушындый чәйләрнең берсендә мин җыелган халыкка түбәндәге документны татарчага тәрҗемә итеп укып чыктым.* Г.Кутуй. *И-и, шушындый оҗмахны ташлап кая китте теге иптәш егетең?* К.Тимбикова. *Чакырылмаган кунак шушындый була ул!* М.Маликова

**ШУЫЛДАТУ** *ф. йөкл. юн. к.* **шуылдау**. *Алдан җил өреп, чыбыкларны шуылдата, колакларда курай уйный...* Ш.Камал. *Ерак та түгел, асфальтны шуылдатып, машиналар узды, станциянең тонык гөрелтесе тоташ ишетелеп торды.* А.Гыйләҗев

**ШУЫЛДА́У** *ф. к.* **жулау**. *Саранчадай шуылдап, Бар шайманы шыңгырап, Бәреп егып аударып, Кыргын кырып бара бирде.* Дастан

**ШУЫТУ** *ф.* 1) Шудыру, шудырып төшерү. --- *кәтиб Хафиз бүлмәсенә табиб Антоний килеп керде һәм керүгә изрәп йоклап яткан кәтиб муенындагы тәрене сак кына ычкындырып алды, кесәсенә шуытты* ---. М.Хәбибуллин. *Аннан сөлгесен идәнгә шуытып төшереп җибәрде дә, сабыйны йомшак чүпрәккә төрде.* Ж.Рәхимов // Шудырып күчерү. *Әминә бер камышны тота да, очына хәтле кулын шуытып, иң очын гына өзеп ала.* М.Фәйзи. *Машинасы янына Галим аякларын шуытып кына атлап барып җитә алды.* Ш.Алпар

2) *күч. к.* **шудыру** (*8 мәгъ.*). *Калайны да, спиртны да, көмешне дә култык астына кыстырып кына шуытып булмый.* Т.Әйди. *Бушаган да калган әрҗә! Төбендә генә бәрәңгесе. Мин юк арада кимендә дүрт-биш тонннаны шуыткан теге кабахәт.* К.Тимбикова

3) *күч.* Үз җаваплылыгыннан, өстеннән төшерү; озатып җибәрү, ычкындыру, олактыру. *Башта маклерский бирергә ышандырып та, соңыннан тегене бер тиенсез шуыткан.* Ш.Камал

**Шуыта башлау** Шуытырга тотыну. *Бөтен гайрәт-дәрманымны туплап, зурайткыч пыяламны тылсымлы юллар өстеннән шуыта башладым.* Ж.Рәхимов

**Шуыта төшү** Аз гына, бераз шуыту. *Алар киемнәрен салмадылар, шәлләрен азрак шуыта төшеп, сәке кырыена гына утырдылар.* Г.Иделле

**Шуытып бетерү** Барысын да шуыту

**Шуытып кую** Алдан шуыту, шуыткан хәлдә калдыру. *Болай дигәч, Сәгыйдә көлеп җибәрә дә калфагын юри артка шуытып куя.* Ш.Камал

**Шуытып тору** Һәрберсен бер-бер артлы, туктаусыз шуыту яки сөйләү моментында шуыту

**ШУЫШМА** *и.* **1.** *геогр.* Елга, күл, диңгез ярларының аскы катлавы җебү, йомшау һ.б. сәбәпле аның өске катлавының урыныннан күчү күренеше. *Идел суы күтәрелгәч, яр буйларында хәтәр шуышмалар барлыкка килде.* М.Рәфыйков. *Шуышмалар торак пунктларга, элемтә юлларына, нефтьгаз үткәргечләргә һәм башкаларга куркыныч тудыра.* География

**2.** *с. мәгъ.* Үрмәләп, шуышып үсә торган; үрмәле. *Уралма кырлач – карабодайчалар семьялыгыннан туфрактан җиңел суырылып чыгучан тамырлы, 40–100 см озынлыктагы шуышма (уралма) сабаклы берьеллык үләнчел үсемлек.* Агулы үсемлекләр. *Башка абагалардан аермалы буларак, бөркет канаты озын шуышма тамырчалы, анда крахмал туплана.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**ШУЫШМАЛЫ** *с. к.* **шудырмалы** (*2 мәгъ.*). *Барыбыз да: «Все, все!», – диеп кычкыргач, шуышмалы авыр ишекне дөбердәтеп яптылар, вагон эче кап-караңгы булып калды.* Г.Гыйззәт

**ШУЫШТЫРУ** *ф.* Шудыру, сөйрәү. *Әсирләр, аякларын шуыштырып атлыйатлый, юлны дәвам иттеләр.* Н.Дәүли

**Шуыштыра башлау** *к.* **шудыра башлау**. *Хәтта кыстап кына да калмады, өлгер-җитез куллары белән табындагы ризыкларны безнең алга шуыштыра башлады.* М.Хәсәнов

**Шуыштырып алу** *к.* **шудырып алу**. *Шаһ-Солтан янә дисбе төймәләрен шуыштырып алды.* М.Әмирханов

**Шуыштырып кую** *к.* **шудырып кую**. *Агай, сүзем бетте дигән шикелле, колакчынлы кәпәчен баш артына шуыштырып куйды.* А.Әхмәтгалиева. *Сафагәрәй кинаяне үз ягына борды. Чынаягын өстәл читенәрәк шуыштырып куйды* ---. М.Әмирханов

**ШУЫШУ** *ф.* 1) Гәүдәне җирдән шудырып, сөйрәп яки үрмәләп хәрәкәт итү. *Аркасына биштәрләгән авыр капчыгы җиргә иңкәйтә, сөйрәгән йөгенең артыннан эз сузылып кала, әйтерсең урман ерып, юан буар елан шуыша.* Г.Якупова. *Үлән каплаган нигез урыннарындагы ташларда кәлтәләр шуыша.* Р.Фәйзуллин // Нинди дә булса өслеккә гәүдә белән елышып, аяклар, куллар ярдәмендә алга этелү, үрмәләү. *Тагын ике солдат, кулларына гранат тотып, дзотка таба шуыша иде.* Г.Әпсәләмов. *– Икегез дә эш кешеләре, балалар, кайчан гына түш белән шуыша идегез, күз алдында үстегез дә киттегез.* Р.Камал

2) Шуу, шуып китү, шуып, урыныннан күчү. *Кызның гәүдәсе тетрәнеп куйды, ә егетнең кулы аның билендә иркәләп шуыша иде.* Х.Камалов. *Мәҗит идәнгә шуышып төште, биш тиенне барып алды да аны тагын бәреп җибәрде.* Н.Фәттах. *Йонлач, сөяксез затның «мин – әҗәл» дип куркытуы янә колак төбендә яңгырагандай булды, Мәдинә, аһын җуеп, идәнгә шуышып төште.* А.Әхмәтгалиева

3) *геогр.* Аскы җир катламының тотрыклыгы, бердәйлеге бетү, җебү, йомшау һ.б.ш. сәбәпле, шуышма барлыкка килү. *Биек тау өстендәге боз әкрен генә, сиздерми генә аска таба шуыша, эри. Төньяктан әкрен генә чиксез зур бозлык шуышкан.* СССР тарихы. *Көндез кызган, киңәйгән ком өемнәре, һава алмашынгач, урын күчә, шуыша.* География

4) Җиргә ятып үрмәләп үсү. *Бу урында тау шулхәтле текә ки, чыршы һәм наратлар кыяга тотынып, ябышып үскән кук, текә ярга түше белән ятып диярлек, артыш куаклары өскә шуыша.* Т.Нәҗмиев

5) *күч.* Убылу, уелып ишелеп төшү. *Аяк астындагы идән каядыр шуыша, түшәм әйләнә сыман тоелды.* С.Зыялы

6) *күч.* Тирә-якка таралу, җәелү, хәрәкәт итү. *Таң беленеп килә, бик шомлы, чык та төшмәгән, күктә сәләмә кара болытлар шуыша, әллә нинди шыксыз җил өзек-өзек исеп куя.* Х.Камалов. *Ишек ачылган саен, трамвайга зәһәр салкын ургылып керә. Керә дә идән буйлап утыргыч асларына шуыша, аннары, тун-пальто чабуларына ябышып, өскә үрмәли.* Г.Гыйльманов. *Тонык яктылык,*

*палата диварларына сыенып, әкрен генә шуыша, үрмәле төсле*. Р.Низами

7) *күч*. Кайсы да булса юнәлештә салмак кына урыныннан күчү, хәрәкәтләнү. *Комбат биноклен күзенә китерде, кечкенәрәк тау артыннан, ике кара колонна булып, танклар шуыша иде*. Х.Камалов. *Пароход су өстеннән салмак кына шуыша*. Р.Батулла

**Шуыша башлау** Шуышырга тотыну. *Газинур дзотка таба шуыша башлады*. Г.Әпсәләмов. *Юлдан пехота, берничә атлы обоз шуыша, ара-тирә мотоцикллар уза иде*. М.Мәһдиев. *Аяк астындагы таш идән дә, җан кергән сыман кинәт убылып, бер якка шуыша башлады*. М.Хәсәнов

**Шуыша бирү** Бернигә карамый шуышу. *Урманов, тешләрен кысып, һаман шуыша бирде*. Г.Әпсәләмов

**Шуыша тору** Һаман шуышуын дәвам итү. *Тәрәзә яныннан таныш түгел авыллар, разъездлар, станцияләр бер-бер артлы артка шуыша торды*. Ф.Латыйфи. *Шулай вакыт акрынлап булса да шуыша тора*. Ф.Яхин

**Шуыша төшү** Аз гына, бераз шуышу. *Рәния, үкси биреп, Рәфиснең күкрәгеннән аерылды һәм, утырган җиреннән шуыша төшеп читкә барып утырды*. А.Вергазов. *– Кешеләргә үпкәләргә, ышаныч югалтырга ярамый шул, – дип сөйләнә-сөйләнә, Аблаев та тәрәзәгә таба шуыша төште*. Р.Мөхәммәдиев

**ШҮР** *и. фар*. Яшелчә, балык, уылдык һ.б.ш.ны тозлау өчен тоз эретелгән су, тоз эремәсе, тозлык

**ШҮРӘЛЕ** *и. миф*. Халык ышануы буенча: урманда яшәүче, кешегә охшаган, йөнтәс какча гәүдәле, кешеләрне озын бармаклары белән кытыклап үтерергә ярата торган бер мөгезле җан иясе; урман иясе. *Урман-әрәмә тулы шүрәле бездә, шүрәлеләрдән дә курыкмыйммы Мәйсәрәң? Шүрәлеләр бит кети-кети уйнарга яраталар*. М.Хәбибуллин. *Ул һаман да шул ук шүрәлеләр, җенпәриләр, шайтаннар, убырлар, Сак-Соклар белән җенләнә*. Р.Миңнуллин

◊ **Шүрәле каргаган** Үсми, үрчеми торган, кечкенә. *Күрәләтә торып җәһәннәм чигендәге шушы шүрәле каргаган авылга килдем бит!* А.Вергазов. *Йортлары аз калган авылларга «Шүрәле каргаган» диләр*. Р.Батулла. **Шүрәлегә су башы күрсәтү** 1) Кемне дә булса адаштыру; алдап, кире якка җибәрү; 2) Алдау, дөресен сөйләмәү. *Зөһрә шүрәлегә су башы күрсәтергә җыенмый – барысын да турыдан яра, бөтенесен уртага салып сөйләшә, егеткә үзенең эч серләрен бушата*. Р.Кәрами

**ШҮРЕ** *и*. 1) Туку станында аркаулык җеп уралган һәм шуны йөртү өчен сосага куярлык итеп эшләнгән куыш эчле кечкенә торба рәвешендәге деталь. *Гайниҗамал абыстай эш эшләгәндә, Фатиха да кул арасына кергәли, кая калдырча әйләндереп шүрегә җеп чолгый, кая әвернә сүтеп йомгак ясый торган иде*. Т.Нәбиуллин. *Гөлчәһрә тагын эш башлый. Шүрегә җеп урый, шүрене сосага кертә дә, сосаны бик оста гына шудырып, аркылы җепне икенче яктан тартып ала да, аягы белән тәбәлдерекне төшереп, палас кылычы белән аркылы җепкә суга ---*. Р.Батулла

2) Тегү машинасында җеп чорнау өчен металл кәтүк

**ШҮРЕЛЕК** *и. диал. к.* **шомакөпшә**. *Иртәнге кояшның матурлыгы, күл әйләнәсендәге камыш һәм шүрелекләрнең вакыт-вакыт күңелле генә тирбәлеп куюлары, күл аръягындагы урман турында нәрсәдер белдерәсем килә*. М.Яһудин

**ШҮРЕ́ СӨЯК** *и*. Кошлар аягында бот белән табан арасындагы куыш эчле сөяк. *Кошларның тәне каурый белән капланган. Арткы очлык бармаклары тырнаклы, ә аякларның аскы өлеше – шүре сөякләре – мөгезматдә тәңкәләр белән капланган*. Биология

**ШҮРЕ́ ҮЛӘНЕ** *и. диал. к.* **шомакөпшә**

**ШҮРЛӘ́Ү** *ф*. Кемнән яки нәрсәдән дә булса бераз курку, куркып калу, өркү. *Усал, гадел врач иде ул, аңардан ярадылар да шүрлиләр иде*. Х.Камалов. *Мондый куркыныч төндә бөтенләй таныш булмаган зират эченнән кайтырга үзем дә шүрлим инде шүрләвен*. М.Вәлиев

**Шүрләп алу** Бераз, берара шүрләү. *Чатырының ныклыгына иманы камил булса да, Зөбәеров тагын шүрләп алды: «Ватар бу күсе мыек»*. Ш.Бикчурин

**Шүрләп йөрү** Озак вакытлардан бирле шүрләү. *Без байтак вакыт Икрами агайдан шүрләп йөрдек*. Г.Ахунов. *Ә мин, белмәгәйләре дип, һаман шүрләп йөри идем*. С.Сабиров

**Шүрләп калу** Кисәк шүрләү; нинди дә булса бер вакыйгадан соң шүрли торган булу. *Егетнең бу башсызлыгыннан шүрләп калган хатын-кызлар чырчу килеп читкә тайпылды*. А.Вергазов. *Габделфәрт, бу шикле егетләрдән баштарак шүрләп калса да: – Эля, мин сине беркая да җибәрмим! – дип әйтмичә булдыра алмады*. Х.Ибраһим

**Шүрләп киту** Кинәт шүрләү. *Ул Андрейдан шүрләп киткән шикелле булды*. Х.Камалов. *Бәлки, «Булгария» теплоходы белән булган фаҗигадан соң күңел ачу урынсыздыр монда, суга, метеорларга караган саен, шул мәхшәрле көннәр искә төшә, шүрләп китәсең...* Шәһри Казан

**Шүрләп кую** Аз гына вакытка, беразга гына шүрләү. *Барый баштарак, Ислам яклылар күбрәк була күрмәсен тагын, дип, бераз гына шүрләп тә куйган иде*. Н.Фәттах. *Көпә-көндез булса да, ни өчендер сәбәбен аңлата алмыйм, мин шүрләп куйдым*. Р.Батулла

**Шүрләп тору** Гел шүрләү; күпмедер вакыт шүрләү; әле, хәзерге вакытта, сөйләп торганда шүрләү. *Шайтан алгыры, гел нәрсәдәндер шүрләп торырга туры килә*. Х.Камалов. *Күршеләр белән чагыштырганда, Сарайгырның халкы азрак. Шулай да бик күпләр бездән шүрләп торалар*. Н.Фәттах

**Шүрли башлау** Шүрләү гадәте барлыкка килү. *Башта син минем белән чак-чак кына мавыктың да шикелле. Инде менә, эшләр тирәнгә китмәгәе, дип шүрли башладың*. Ф.Хөсни. *Бу вакыйгадан соң Мирвәлидән балалар гына түгел, укытучылар да шүрли башлады*. Р.Батулла

**Шүрли калу** Кинәт кенә шүрли башлау. *Мондый әкәмәтне элек беребезнең дә күргәне булмаганга, әзрәк шүрли калдык*. А.Тимергалин. *Гөлбану бер бәләкәй генә өй янында өстенә кызгылт чикмән кигән зур гына сакаллы бер кешене күреп шүрли калды*. М.Хәсәнов

**Шүрли төшү** Бераз шүрләү; тагын да ныграк шүрләү. *Су анасы турында ишеткәч, Барый тагын да шүрли төште*. А.Гыйләҗев. *Бай сәүдәгәрләрдән һәр чыгарган өчен өстәмә хак җыярга өйрәнгән әрсез халык никтер Сүбәдәй баһадирдан бераз шүрли төшә иде*. М.Хәбибуллин

**ШҮРЛӘҮ** II *и*. Берәр нәрсә алдында көчсез, ярдәмсез булудан я шулай дип уйлаудан, шикләнүдән туган рухи-физиологик халәт. *Ләкин Әсмада, эттән курку хисеннән бигрәк, Мәймүнә күзенә чалынудан шүрләү хисе көчлерәк булды ---*. З.Хөснияр. *Һәрхәлдә, аларның йөзендә башкаларныкындагы шикелле шүрләү галәмәте сизелми иде*. М.Кәбиров

**ШҮРЛӘҮЛЕ** *с*. **1.** Куркулы, өркүле, курку, өркү чагылган. *Шүрләүле караш. Шүрләүле кыяфәт*

**2.** *рәв. мәгъ.* Шүрләгән, куркынган хәлдә, шүрләп, куркып. *Үзе елмаерга тырыша, кулларын селти, үзе һич яшерә алмастай шүрләүле төстә Зөлхәбирәгә карап-карап куя.* Р.Төхфәтуллин

**ШҮРЛӘҮЧӘН** *с.* Шүрле, өркә, курка торган, өркәк, куркак. *Озатучы мәрхәмәтле җаннар китүгә, караңгыда шүрләүчән Искәндәр нәни йодрыклары белән капканы төяргә тотынды.* А.Гыйләҗев

**ШҮРЛЕК** *и.* 1) Савыт-саба, китап, вак-төяк кирәк-яраклар кую өчен стенага беркетеп эшләнгән аркылы өслек; киштә. *Шул арада самавырын да гөрләтеп кайнатты, кечкенә ачык агач шүрлектән чынаягын, икмәген, чәй-шикәрен дә, алып, буяусыз агач өстәлгә тезде.* Г.Ибраһимов. *Китап шүрлегеннән зәңгәр тышлы строевой уставны тартып чыгарды.* С.Шәрипов // Әйберләрне тезеп кую өчен стенага беркетелгән такта яки үзе стена итеп эшләнгән киштәләр тезмәсенең бер тактасы. *Ул әледән-әле магазиннарга керде, шүрлекләргә тезеп куйган ялтыравык ботинкаларга, курчакларга, костюмнарга, төрле бизәктәге материя төргәкләренә карап торды.* Н.Фәттах. *Бу вакытта исә Гофран абзый, ыштан кесәсеннән янчыгын чыгарып, акчаларын кармаштыра, ә күзләре белән кибет шүрлекләрен ялый иде.* М.Мәһдиев

2) Шкафның аерым бүлекчәсе. *Жандарм, урындыкка басып, китап шкафының өске шүрлеген карарга тотына.* Г.Мөхәммәтшин. *Ул ачудан стенка шүрлеген алып атып, аннан анализ кәгазьләрен тартып чыгарды.* Ахир

3) *күч. сөйл.* Авыз. *Әй, юл бир! Малай, шүрлегеңне бик күтәрмә, карга йомырка салыр.* И.Салахов

◊ **Шүрлеген җимерү** Кыйнап, авызын җимерү

**ШХЕРЛАР** *и. күпл. швед диңгез.* Төньяктагы диңгез һәм күлләрдә яр буйларында зур булмаган су асты кыялары; ярның шундый кыялар булган урыны. *Өсләрен кар каплаган меңнәрчә кечкенә атаулар һәм шхерлар катып калган дулкын сыртларын хәтерләтәләр ---.* З.Воскресенская

**ШХУ́НА** *и. ингл.* Ике яки өч мачталы кыек җилкәнле судно. *Берәүләр – тракторга, икенчеләре – тепловозга, өченче берәүләр – космик корабльгә, дүртенчеләр балык шхунасына гашыйк булалар.* М.Мәһдиев. *Пиратларның җилкәнле җиңел шхуналары --- килеп туктарга, тау куышларына кереп яшеренергә --- була.* А.Хәсәнов

**ШЫБЫН** *и. иск. мар. к.* **шомпол**. *Аны бит мылтык шыбыны белән суктырганнар иде.* Т.Гыйззәт. *Әнә теге шомырт куагыннан Харис шыбын кебек төз чыбык кисеп алган иде бит.* Н.Фәттах

**ШЫБЫНЛА́У** *ф.* 1) Шыбын белән чистарту (мылтык көпшәсен)

2) *к.* **шомполлау** (*2 мәгъ.*). *Ат хуҗасы авылы кешеләре – удмуртлар килеп, Бикәне шул урында тотканнар һәм, самосуд ясап, шунда шыбынлап үтергәннәр.* Р.Зарипов

3) *диал.* Берәр нәрсәнең эчен, чокыр яки тишекне шыбын, таяк яки шундый нәрсә белән бутау, гөҗгеләү. *Йомран тишеген шыбынлау. Тиен оясын шыбынлап, чикләвеген алу*

**ШЫБЫР** I *и.* Идел-Кама төбәгендә татар, чуваш, марилар арасында таралган, эченә һава тутырылган карыннан гыйбарәт капчык формасындагы традицион музыка коралы – волынканың бер төре. *Шыбыр тавышы басылгач, Туй җырлары башлана.* Ш.Мөдәррис

**ШЫБЫР** II *кис. к.* **шабыр**. *Гази шыбыр тиргә батып уянып китте.* М.Хәсәнов. *Шигырьләрне кызыксынып укырга тотынса да, берәрсен ятлап килергә дисәләр, Җәмил шунда ук шыбыр суга бата иде.* Н.Әхмәдиев

**ШЫБЫРДАП** *рәв.* Барысы бердән, дәррәү. *Бәлки, бу дуамал ашкыну сүрелер, ә тиле уйлар шыбырдап баштан коелыр иде.* Н.Гыйматдинова

**ШЫБЫРДАТУ** *ф. к.* **шабырдату**. *Өстендәге япмасын сыпырып төшерделәрмени, ул, ялангач гәүдәсен капларга маташкандай, яфракларын шыбырдатты ---.* Н.Гыйматдинова. *Авылга илтүче юлдан челтер-челтер гөрләвекләр ага, эре яңгыр тамчылары, кипкән агач яфракларын шыбырдата-шыбырдата, җиргә тамалар.* Безнең мирас

**Шыбырдатып алу** Тиз генә шыбырдату. *Адашкан җил имән яфракларын шыбырдатып алды.* А.Хәлим

**Шыбырдатып җибәрү** Кинәт шыбырдата башлау. *Әбиләр чуагының бу соңгы җылы, шаян җиле шиңә башлаган яфракларны шыбырдатып җибәрә.* Г.Әпсәләмов

**ШЫБЫРДА́У** *ф.* 1) *к.* **шабырдау**. *Ашлык төягән арбалар шыгырдый, бертуктамый яңгыр шыбырдый.* А.Алиш. *Түшәмнән шыбырдап ком коелды.* Г.Әпсәләмов. *Хәзер күзгә һичнәрсә күренеп тормаса да, башаклар һаман элеккечә кыштырдый, яфраклар элеккечә шыбырдый.* Ә.Баян

2) *күч. гади с.* Күп сөйләү; белер-белмәс кирәкмәгәнне, сөйләргә ярамаганны сөйләү, лыгырдау. *Гәҗитәдән пирчәткә бармакчасы хәтле генә апа килгән иде. Әй чәтерти бу, әй шыбырдый, коелмый гына. Ну, мәйтәм, лагерьда очраган булсаң, сидереп сидегеңә утырта идем мин сине!* А.Гыйләҗев. *– Без яшьләрне үстерергә тиештер бит. Мин арыдым, тарта алмый башладым. – Сезнең оешмада парторг булырлык кеше күренми әлегә. Шыбырдамый гына эшлә. Юкса үзең беләсең!* Х.Камалов // Урынсыз яки кирәксез сүз сөйләү, әйтү. *Наилә түзмәде: «Нигә кунаклар килеп җитми соң?» – дип шыбырдады.* А.Гыйләҗев

**Шыбырдап алу** Аз гына шыбырдау. *Серкә койган арыш басуында Йөгерәйөгерә уйный таң җиле. Су буенда тал шыбырдап ала, Төшләр күргән бала шикелле.* З.Мурсиев

**Шыбырдап җибәрү** Кинәт шыбырдый башлау

**Шыбырдап кую** Бер тапкыр шыбырдау. *Яңгыр шыбырдап куя...* С.Хәким. *Кинәт яфраклар шыбырдап куя.* Сөембикә

**Шыбырдап тору** Өзлексез шыбырдау; хәзер шыбырдау. *Мин гомумән төнге яңгырны бик яратам. Хәзерге кебек салмак, ләкин еш һәм тигез генә, җиңел генә шыбырдап торса, бөтен җаным белән биреләм.* Г.Ибраһимов. *Яңгыр монда хәтта шәбрәк ява шикелле тоелды – бөтен тирә-як шаулап, шыбырдап тора иде.* Н.Фәттах

**Шыбырдый башлау** Шыбырдарга тотыну. *Иске балалар тудыру йорты артындагы тыкрыкка керүгә, Артём Парсегян шыбырдый башлады, ул кая килгәннәрен аңлады, чөнки бу урам прокуратура ишегалдына терәлеп тора, ләкин авыз ачып берни әйтмәде.* Р.Мирхәйдәров. *Берәр нәрсә шыбырдый башласа, шунда ук качалар.* Акчарлак

**ШЫБЫРДАШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **шыбырдау**. *Малайларга сиздермичә генә, шырпы кабын кулыма алдым, чикерткәләр шыбырдашалар иде әле.* Р.Миңнуллин. *Шыбырдашып утырган яшьләрнең күбесе Җәмилә Закировнаның беренче әйткәннәрен ишетми дә калды шикелле.* М.Маликова. *Малайлар гына: «Әби, без кыр үрдәге күрдек!» – дип шыбырдаштылар.* А.Гыйләҗев

**Шыбырдаша башлау** Шыбырдашырга тотыну. *Балалар икенче якка тайпылып юл бирделәр дә янә яңгыр тамчыларыдай шыбырдаша башладылар.* Ф.Җамалетдинова. *Тәрәзә төбендә яңгыр тамчылары шыбырдаша башлады ---.* Ә.Мушинский

**Шыбырдашып алу** Аз гына шыбырдашу. *Егетләр бераз шыбырдашып алдылар, чыпчык ташы яңадан алга чыкты.* М.Мәһдиев. *Утлар сүнде. Кешеләр яңгыр тамчыларыдай бердәм шыбырдашып алдылар.* Ф.Җамалетдинова

**Шыбырдашып кую** Бер тапкыр шыбырдашу. *Таллар аны таныган төсле җанланып, шыбырдашып куйдылар.* Р.Миңнуллин. *– Уф, – диде. Уфыруыннан йокымсыраган яфраклар шыбырдашып куйды.* Н.Гыйматдинова

**Шыбырдашып тору** Туктаусыз шыбырдашу; әле, хәзер шыбырдашу

**ШЫБЫРДЫК** *с. сөйл.* 1) Шыбырдый торган, шыбыр-шыбыр тавышланып торган. *Шыбырдык усакларның үзара серләшүен тыңлап, сәгатьләр буе аунап ятарга яратам.* Г.Сабитов

2) *күч.* Лыгырдык, күп һәм буш сүз сөйләүчән, телчән. *Әсәрнең икенче сызыгына --- редактор Рәкыйп, шыбырдык хатын Ниса Чәймиева гаделлек һәм гаделсезлек --- гадәтләрен чагылдыручы образлар булып килеп керәләр.* Г.Ахунов

**ШЫБЫРТ** *иярт.* **1.** Әйберләр шыбырдап кинәт коелып алганда чыккан тавышны белдерә

**2.** *хәб. функ.* Шыбырдатып салу, кою. *Нарат җиләген чүгәләп, тезләнеп сыдырырга керешәсең. Бер сыдырасың, ике сыдырасың – учың тула яза. Аннары шыбырт котелокка.* Э.Касыймов

**ШЫБЫ́Р-ШЫБЫР** *иярт. к.* **шабыр-шобыр**. *Тулышкан башаклар гына бер-берсенә бәрелешеп зең-зең итә. Менә җил көчәер дә, алтын бөртекләр шыбыр-шыбыр җиргә коелыр төсле.* Н.Гыйматдинова. *Кешеләр өстән шыбыр-шыбыр туфрак төшерә башладылар.* Ш.Гариф

**ШЫГАВЫЛ** *и. тар.* Ишек сакчысы. *Хан сарае ак ишек, Бер ишектә Аңгысын, Бер ишектә Тыңгысын – Ике торган шыгавыл Туктамыш хан колы иде.* Дастан. *Кунак шуннан соң гына ишек катына шыгавыллар баскан сарайга игътибар итте.* В.Имамов

**ШЫГАЙТУ** *ф. сөйл. йөкл. юн. к.* **шыгаю**. *Ә үзенең бер-ике кочак печән төялгән кул арбасы шуннан ерак та түгел, чикләвек куаклары артына шыгайтып куелган.* В.Нуруллин

**ШЫГАЮ** *ф. сөйл. к.* **шыкаю**. *Киң җилкәле, үзеннән бер башка олы үсмер егеттән шыгаеп, Фатих хәлфә читкәрәк тайпылды.* Г.Ахунов. *--- баржа корпусларын җыйганда, табаклы тимерләр җилкәңнән үтә, заклёпка вакытында чүкеч сугасың, --- бик тирләсәң, мастер күзеннән шыгаеп, тиз генә чумып аласың.* Ф.Хөсни

**Шыгаеп тору** Билгеле вакытны шыгайган килеш уздыру. *«Мин айгырны алып, урман тирәсендә шыгаеп торам», – ди Корбангали абзый.* Мөлкәтебезне барлаганда

**ШЫГРЫМ** *кис.* Бер буш урын да булмаган, тыгызланып тулган, тутырылган, тәмам тулган, туп-тулы. *Баржа эче балалар белән шыгрым тулы.* Ә.Баян. *Филармониянең концерт залы тамашачылар белән шыгрым тулган.* Г.Макаров

**ШЫГРЫМЛА́У** *ф. сир.* Шыгрым тутыру, шыгрым тулы итү. *Әй сагындырган икән Камал театры бинасын шыгрымлап тутырып уздырылган ул кичәләр.* Сөембикә

**ШЫГЫРДАВЫК** *с.* **1.** 1) Шыгырдап тора, шыгырдый торган, шыгыр-шыгыр итә торган. *Шыгырдавык кар өстеннән аяк тавышларын үзе дә ишетмәстәй атлап, Мөнирҗан мунчага юнәлде.* Н.Әхмәдиев. *Асаф, кешеләрнең тез башларына бәрелә-бәрелә эчкә узып, буш калган шыгырдавык тәрәкле бер урындыкка утырды ---.* М.Мәһдиев

2) *күч.* Арба шыгырдавына охшаш, карлыккан, ямьсез. *Музыка тавышы тынып, Василий Михайловичныкына охшаш ямьсез, шыгырдавык тавыш ишетелү белән, Габделхәй айнып киткәндәй булды.* Н.Фәттах. *--- һәр йорт яныннан үткәндә, шыгырдавык тавышы белән сукранып куя: – Барыгызны да аттырасы калган, ышбулышлар!* Ф.Баттал

3) *күч.* Чирләшкә // Зарланучан

**2.** *и. мәгъ.* Сәламәтлеге булмаган, чирләштереп торган, ыңгыр-шыңгыр йөргән кеше. *Тапты үләр вакыт. Ярамаганмыни җәй көне, корырак, җылырак вакытта. Ике кулсыз итте бит, шыгырдавык.* М.Мәһдиев

**ШЫГЫРДАВЫКЛЫ** *с.* **1.** *к.* **шыгырдавык**. *Мин, кибетнең шыгырдавыклы ишеген ачып, урамга чыктым.* Гали Рәхим. *Хәлсезлектән калтыранганга күрә, элеккедән дә ямьсезрәк яңгыраган шыгырдавыклы тавышы белән сөйли башлады ---.* Казан утлары

**2.** *и. мәгъ.* Ике кешенең арканы аркага куеп, берсенең кулларын икенчесенекә белән чалыштырып, әле берсе, әле икенчесе бер-берсен күтәрүдән гыйбарәт уен. *Пәрдә ачылганда, шәкертләр шыгырдавыклы уйныйлар.* Т.Гыйззәт

**ШЫГЫРДАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **шыгырдау**

2) Шыгырдаган тавыш чыгару. *Шәмсүн көрсенеп куйды һәм, агач караватны шыгырдата-шыгырдата, урынында авыр әйләнеп, түшәмгә карап ятты.* А.Вергазов. *Шомыршы юлының салкын карын нинди итекләр шыгырдата дисәң, Төке мукшылары баскан җылы итекләр!* Н.Хисамов

3) Шыкырдаган тавыш чыгару, шыкырдату. *Блоковойлар капка төбенә тезелеп баскач, алар алдына лагерь комендантшы Кампе үзе чыкты. Күзләрен кан баскан, тешләрен шыгырдата, иреннәрен чәйни.* Г.Әпсәләмов. *Зарифуллин тешен шыгырдата, Гыйззәтуллин, авызын чап-чоп китереп саташып, нәрсәдер ашый иде.* М.Мәһдиев

4) *күч.* Уен коралында, гадәттә гармунда аз-маз уйнау, азрак уйный белү. *Кәрим белән Сәлим аз-маз гармун шыгырдаталар икән, шул җөмләдән берсе хромканың тавышы шәп, икенчесе тальянка моңлы, дип бәхәсләшеп киттеләр.* З.Мурсиев // Белер-белмәс уйнау, тарткалап тавыш чыгару. *Аннан салмак кына «Яшь наратлар» көен уйный башлады. Белеп уйнавы түгел. Гармунны елата, шыгырдата, интектерә генә.* И.Нәбиуллина

**Шыгырдата башлау** Шыгырдатырга тотыну. *Халык исеменнән эш итәргә күнеккән авторитар хакимият, чын халык идарәсенә килгәндә, тешләрен шыгырдата башлый.* И.Әмирхан. *Хәзер ул баскычлары төбендә уникe телле тальян гармунында уйнарга өйрәнеп утыра. Берничә көй дә чыгара инде. Әнә әни дә: «Бу малай галәмәт шыгырдата башлаган», – ди.* С.Зыялы

**Шыгырдата бирү** Шыгырдатуны дәвам итү. *Яралы тынычланды, күз кабаклары ябылды. Ләкин һаман тешен шыгырдата бирде.* Х.Камалов

**Шыгырдатып алу** Бераз яки бер тапкыр шыгырдату. *Гармунны бераз шыгырдатып алгач, Махно яңадан иске эзгә кайтып төште.* З.Фәтхетдинов. *Йодрыгын кысып тоткан Чанышев яман гына тешен шыгырдатып алды.* Х.Ибраһим

**Шыгырдатып җибәрү** Кинәт шыгырдату, көтмәгәндә шыгырдату

**Шыгырдатып кую** Бер тапкыр шыгырдату. *– Чепу-ха! – диде әти, зәһәр елмаеп, һәм урындыгын шыгырдатып куйды.* Ә.Еники. *Әхмәтхан ярсуыннан тешләрен шыгырдатып куйды.* Р.Камал

**Шыгырдатып тору** Даими яки әледән-әле шыгырдату; әле, хәзер шыгырдату. *Андрей беравык яңак сөякләрен шыгырдатып торды.* В.Имамов

**Шыгырдатып яту** *сөйл. к.* **шыгырдатып тору**

**ШЫГЫРДА́У** *ф.* 1) Нәрсә дә булса шыгыр-шыгыр килү, шундый тавыш чыгу. *Майламаган чыгыр шыгырдый, чыгыр баганалары дер-дер киләләр ---.* А.Гыйләҗев. *Җил исеп юкәләрнең коңгырт кәүсәләре шыгырдый-шыгырдый чайкалып куйганда, бу алтынсу болытлар, җемелдәп-ялтырап, офыкка төшеп баручы кояшка таба агылалар төсле.* А.Вергазов

2) Шыгырт-шыгырт итү. *Аяк астында март аеның төнге салкыннан бозланып каткан кары шыгырдый иде.* М.Маликова. *Аның дагалы итекләре шыгырдый, авыр гәүдәсеннән идән сайгаклары сыгылып-сыгылып кала иде.* Ф.Латыйфи

3) *күч.* Нәрсәгәдер ризасызлык, канәгатьсезлек белдереп зарлану, сукрану. *Эшләтә дә белде ул аларны, бер көн сабактан да калдырмады. Шыгырдый башласалар, өстәлгә шык-шык бармак кына сугып куяр иде, тегеләр шунда ук каз бәбкәләредәй тезелешеп чыгып китәләр...* Р.Төхфәтуллин // Теләр-теләмәс, сукранып кына риза булу. *[Якуб Гафияткә:] Син икмәгеңне бирмәссеңме? Бирерсең! Шыгырдарсың, мыгырдарсың, ләкин бирерсең!* И.Гази

4) *күч.* Сәламәтлек булмау, чирләштереп тору; авыру, хәлсезлек аркасында ыңгырашып, авырсынып ыңгыр-шыңгыр йөрү. *– Зарар юк, – «президент» мәгънәсез генә кулын селтәде, – утырыгыз. Картлар шыгырдый инде ул, менә сез, яшьләр, бирешмәгез.* Г.Әпсәләмов. *Әниебез өч бала били: Зәйнәп исемлесе бик бәләкәй чакта ук дөнья куя; апам Фәүзия исән-сау; без фәкыйрегез шыгырдап алгаласа да яши бирә.* К.Миңлебаев // Чирләп яту, авырып тору. *Исмәт байның шыгырдавы беренче түгел иде.* Г.Әпсәләмов

5) *күч.* Тынычсызланып шыңшу, елау. *Аннан соң икенче бәби дә кыбырсый, шыгырдый башлады.* Р.Батулла

◊ **Шыгырдап торган** 1) Өр-яңа, таушалмаган. *Мудры, --- утырган җиреннән үрелеп, кыеш аяклы өстәлгә шыгырдап торган өч иллелекне чөйде.* А.Гыйләҗев. *Атна-ун көн чамасы икеләнеп йөргәннән соң, Тәкый абзый тәкәне сатып җибәрде дә шыгырдап торган күн итек алып киде.* Г.Сабитов; 2) Кулланылмаган, куллануда, файдалануда булмаган. *Төнлә су килгән икән, ул кранны чак кына ачып коенды, аннары бүлмәсенә кереп, тумбочка эченнән шыгырдап торган җәймәләрен алды да диванга урын җәйде.* М.Маликова; 3) Тынны куырып ала торган, коры, чатнама. *Шыгырдап торган коры салкын. Авыл өсте зәңгәрсу-якты.* Ә.Еники. *Моннан җитмеш биш ел элек шыгырдап торган гыйнвар иртәсендә Вәли абый белән Фатыйма апа гаиләсендә алтынчы бала булып бер малай дөньяга аваз сала.* Г.Шәйхи

**Шыгырдап алу** Бераз яки бер тапкыр шыгырдау. *Ул арада иң биек агачлар гына сизәрлек талгын җил исеп ала, --- кәүсәләрен зәңгәр сакал баскан карт кара чыршыларның берсе котчыккыч чиркәнеч тавыш белән шыгырдап ала ---.* М.Мәһдиев. *Караваг шыгырдап алды да тынды.* Р.Вәлиев

**Шыгырдап кую** Бер тапкыр шыгырдаган тавыш чыгару. *Урындыклар шыгырдап куйды.* М.Мәһдиев. *Диван пружиналары шыгырдап куйды.* М.Маликова

**Шыгырдап тору** Өзлексез яки әледән-әле шыгырдау; әле, хәзер шыгырдау. *--- тәбәнәк таш өйнең биек баскычы баскан саен ишелеп төшәргә әзер булып, селкенеп, шыгырдап тора.* Н.Фәттах. *Иреннәренә ком, көл кунган, хәтта авыз эчендә дә тәмсез, әчкелтем-тозлы тузан, тешкә тиеп, шыгырдап тора.* Г.Гыйльманов

**Шыгырдый башлау** Шыгырдарга тотыну. *Элемтәченең катушкасы әкрен генә шыгырдый башлады.* Г.Әпсәләмов. *Ул арада алгы тәгәрмәчләрнең берсе ямьсез генә шыгырдый башлады.* А.Гыйләҗев

**Шыгырдый бирү** Бернигә карамый шыгырдау. *Вакыт арбасы үз көенә тәгәри бирә. Кайчакларны, хет беразга гына туктатып, көпчәкләрен, күчәрләрен майлап алырга бик кирәк. Туктамый шул, бер көйгә шыгырдый бирә.* А.Хәсәнов. *Дәвешләргә чаклы бергә атлаулары мөмкин иде, ләкин Палҗан артык тәкәббер булганга күрә, артыннан күршесе ияргәнен бар дип тә белмичә, шыгырдый бирде.* Ә.Баян

**ШЫГЫРДАУЛЫ** *с. к.* **шыгырдавык**. *Ә менә хәзер, эшен тәмалагач, --- нindидер аңлашылмаган тупас шыгырдаулы әлеге тавыш, әйтерсең лә ярык агач торба аша чыгып, нәкъ аның колакларында яңгырый.* Җ.Ильясов

**ШЫГЫРДЫК** *с. к.* **шыгырдавык**. *Такталары кайшалып беткән шыгырдык сәке.* С.Поварисов. *Әллә анда берәр нәрсәгезне онытып калдырдыгызмы югыйсә? – диде бу әби ризасызлык белдергән шыгырдык тавышы белән.* Р.Фәизов. *Алар, өсләренә кигән туннарын төймәләргә дә онытып, шул шыгырдык кар сукмаклардан чаптылар.* Л.Ибраһимова

**ШЫГЫРТ** *ияpт.* Агач, каты кар һ.б.ш. коры, уалучан нәрсәләр кисәк сынганда, уалганда, ышкылганда чыккан өзек, яңгыравык тавышны һәм шулай кисәк сыну, уалу рәвешен белдерә. *Йомшак кар өстенә каз-үрдәк тармаклы-җәпләкәле беренче эзләрен салып киткән. Кич-иртә урамнан шыгырт та шагырт аяк тавышлары ишетелә.* Г.Бәширов

**ШЫГЫ́РТ ИТҮ** *ф.* Шыгырт иткән тавыш чыгару. *Шыгырт итеп ишек ачыла да, аннан я сестра, я авырулардан берәрсе килеп керә.* Р.Төхфәтуллин

**ШЫГЫ́РТ-ШАГЫРТ** *ияpт.* Төрле югарылыкта чыккан, ритмик кабатланган шыгырдау тавышын һәм шундый шыгырдау рәвешен белдерә

**ШЫГЫ́РТ-ШЫГЫРТ** *ияpт.* Агач әйберләр бер-беренә ышкылып киткәндә, кар өстендә атлап йөргәндә һ.б.ш. вакытта хәрәкәт иткән саен өзек-өзек чыккан, ритмик кабатланган, өзелеп калган шыгырдау тавышын һәм шундый шыгырдау рәвешен белдерә. *Алар артыннан --- шыгырдавыклы кәвеш кигән кояз кешеләр сыман, атлаган саен аякларын шыгырт-шыгырт иттереп салмак атлап, сыерлар кайтып килә.* Г.Бәширов. *--- бакча ягында Дәүләтгәрәй абзыйның, шыгырт-шыгырт китереп, коедан су алганы ишетелде.* Н.Фәттах

**ШЫГЫ́РТ-ШЫГЫРТ ИТҮ** *ф.* Шундый тавыш чыгару. *Аягында --- яңа кәвеш кебек баскан саен шыгырт-шыгырт итә торган өр-яңа чабата.* Г.Бәширов. *Бар җиһанны ялтыраткан кояш нурларына кар бөртекләре энҗедәй җемелди, аяк асты шыгырт-шыгырт итә ---.* Р.Кәрами

**ШЫГЫ́РТ-ШЫГЫРТ КИЛҮ** *ф. к.* **шыгырт-шыгырт итү**. *Шомырт, аягүрә баскан килеш, кәүсәләре шыгырт-шыгырт килеп ыңгырашып куя, корыган ботаклары чыртлап сынып төшә.*

Ф.Мөслимова. *Баскан саен, җирдә кар шыгырт-шыгырт килә.* Сөембикә

**ШЫГЫ́Р-ШАГЫР** *иярт. к.***шагыр-шогыр**. *Атлар, дөяләр җигелгән чаналарга барлык җиһазларын --- төяделәр дә, сыерларын, сарыкларын арттан куып, әкрен генә, шыгыр-шагыр Камыскүлгә сәфәр чыктылар.* Н.Фәттах

**ШЫГЫ́Р-ШАГЫР ИТҮ** *ф. к.* **шагыр-шогыр итү**. *Алачык эчендәге өч аяклы өстәлне һәм шыгыр-шагыр иткән тапчанны элеккеге хуҗалар калдырган.* А.Хәсәнов

**ШЫГЫ́Р-ШАГЫР КИЛҮ** *ф. к.* **шагыр-шогыр итү**

**ШЫГЫ́Р-ШЫГЫР** *иярт.* **1.** Коры агач ышкылганда, кардан басып йөргәндә һ.б.ш. очракларда бертуктаусыз яки әледән-әле ритмлы рәвештә чыгып торган шыгырдау тавышларын һәм шулай шыгырдау рәвешен белдерә. *Тышта шыгыр-шыгыр кар шыгырдаган аваз ишетелде.* М.Хәсәнов

**2.** *с. мәгъ.* Шыгырдый торган, шыгырдавык. *Кызыл Армия командиры була алмадым бит, әй, гәрчә кокардалы фуражка, --- шыгыр-шыгыр хром итек миңа бик килешсә дә.* А.Хәсәнов

**ШЫГЫ́Р-ШЫГЫР ИТҮ** *ф.* Шундый тавыш чыгару. *Итекләр шыгыр-шыгыр итеп кенә тора, әй.* З.Зәйнуллин. *Ат арбасының тәгәрмәчләре шыгыр-шыгыр итә.* Н.Гыйматдинова. *Чана табаннары карны шыгыр-шыгыр итеп кыршып, җырлап баралар.* Р.Зарипов

**ШЫГЫ́Р-ШЫГЫР КИЛҮ** *ф. к.* **шыгыр-шыгыр итү**. *Идән такталары шыгыр-шыгыр килде ---.* Г.Бәширов. *Ә өстә, зиратта, карт агачлар салкыннан шыгыр-шыгыр киләләр.* Г.Әпсәләмов. *Шыгыр-шыгыр килде тәгәрмәч.* Л.Шәех

**ШЫЕЛДАП** *рәв.* 1) Һаваны ярып, сызгырган тавыш чыгарып

2) *күч.* Бик тиз; зур тизлек белән, выжлап

**ШЫЕЛДАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **шыелдау**. *Ике мотоцикл, бер җиңел автомобиль, аның кул күтәреп торуын бар дип тә белми, шыелдатып узып китте.* Т.Әйди

2) Сыздыру, берне сугу. «*Кем баласы?» – дигәнгә каршы тагы, муенын кыйшайтып, җиңен чәйнәде, авыз ачарга курыкты, ялгыш әйтер дә, хәлфә үзенең озын чыбыгы белән шыелдатыр кебек тоела иде.* Г.Ибраһимов

**Шыелдата башлау** Шыелдатырга тотыну. *Шәкерт озын чыбыгын алды да яртылай йоклап беткән малайлар өстеннән: – Әлиф ят! Әлиф ят! – дип, бер уңга, бер сулга шыелдата башлады.* Г.Ибраһимов

**Шыелдатып алу** Кыска вакыт эчендә, тиз генә шыелдату

**Шыелдатып кую** Бер тапкыр шыелдату. *Тышта пычкы шыелдатып куйдылар*

**Шыелдатып тору** Озак, даими рәвештә яки сөйләү моментында шыелдату

**ШЫЕЛДА́У** *ф.* 1) Җил яки ни дә булса зур тизлек белән һава ярып, нечкә аваз чыгару. *Зенит снарядлары шыелдап очалар.* И.Гази. *Туктамышның кыйбласы күренмәде, соңгы мәртәбә чатыр корган җирендә шыелдап җилләр исә.* Р.Мингалим, Р.Хәмид

2) Каты әйберләр ышкылып, сызгыруга охшаган тавыш чыгару. *Авыл ягыннан балта тавышлары, пычкы шыелдаганы ишетелә.* Г.Бәширов. *Шыелдап барган чанада кулын болгап, кычкыра беренче хәбәрче булып: – Патша мәтәлгән! Ура!..* С.Баттал. *Кыл кебек тартылган трослар әкрен генә шыелдап шуышырга тотынды.* Ф.Абдуллин

3) *күч.* Иреннәрне кысып, теш арасыннан гына усал итеп сөйләү, нәрсә дә булса әйтү; ысылдау. *– Актык мәртәбә әйтәм, акылсыз булмагыз! – дип шыелдады Кампе.* Г.Әпсәләмов

**Шыелдап алу** Кыска вакыт аз гына шыелдау

**Шыелдап кую** Бер тапкыр шыелдау

**Шыелдап тору** Озак, даими рәвештә яки әле, сөйләү моментында шыелдау

**Шыелдый башлау** Шыелдарга тотыну. *Менә репродукторлар шыелдый башлады.* Г.Әпсәләмов

**ШЫЕЛДАШУ** *ф. урт. юн. к.* **шыелдау**. *Шыр ялангач агачларның ботаклары җилдә шыелдашалар.* Р.Ильяс. *Бүтәннәреннән беразга соңарган яшь шомыртлар, яшь каеннар, шыелдашып, яфрак яралар төсле.* Р.Гариф

**ШЫК** I *иярт. к.* **шак**. *Шык та шык! – кемдер тәрәзәгә чиертә берзаман.* Г.Тукай. *Кошчыклар томшыклары белән шык та шык веранда тәрәзәсенә бәреләләр.* А.Хәсәнов

**ШЫК** II *и.* Ямь, матурлык, гүзәллек. *[Бал корты] кайта да кунып ала кортсыз җиргә. Шык бирә пәри тормас шыксыз җиргә.* Ш.Бабич. *Сөйләделәр аның турында: «Юаш кына егет иде илдә. Карап торсаң, исең китмәс бер дә», «Ләкин, – диләр кызлар шул чакта. – Шык бар иде зифа буенда».* Ш.Маннур

◊ **Шыгыннан чыгу** Ямьсезләнү, яме бетү. **Шыгы юк** *к.* **шыксыз**

**ШЫКАЮ** *ф. диал.* 1) Хәрәкәтсез катып калу, хәрәкәтсез тору; сыны катып калу. *Нәрсәгә шыкаеп торам соң әле? Эш күрмәгән кешеме әллә мин? Пешерә дә беләм, кыздыра да беләм.* Ю.Әминев // Туктау, хәрәкәтсез калу; акмый башлау. *[Гали:] Кандыр [елга] ике ташны күтәргән диген, ә хәзер көчкә-көчкә бер ташны өстери дисәңче. Челләдә бөтенләй шыкаймаса дип куркам.* К.Тинчурин

2) Саграк, уяурак, игътибарлырак эш итәргә тырышу, абай булу. *Билал дәшми. Ул Гөләемгә караган да аның сөйләгәнен, ачылганын көтә. Мондый чакта саксыз сүз ычкындырырмын дип тә шыкая ---.* М.Вәлиев. *Таеп егылудан шыкаеп тиз-тиз теркелдәргә тырыша, авыл чынлап уянганчы, басу капкасын чыгып каласы килә, шуңа кабалана.* Р.Мулланурова

3) Берәр нәрсә артына, эченә яшеренү, качу, посу. *Эшнең нәрсәдә икәнен сизгән Гөлчирә морҗа артынарак шыкайган була, ләкин күрәчәгенә каршы, күзлекнең юнәлеш секторына эләгә дә, гипнозланган куянның питон авызына үзе килеп кергәне кебек, Вәлиуллинага таба атлый ---.* М.Мәһдиев. *Горком бинасына барып керүгә, аста, вестибюльдә аны Иван Мөхәммәтович табып алды. Бер почмакка шыкайдылар, башлыкның чырае гадәттәгечә мөлаем һәм хәерхаһ иде.* Ф.Садриев

4) Курку, куркып калу, шүрләү. *Егет, хәтәр шүрләп, күзләрен акайтты һәм җәһәт кенә торды да, бәладән башаяк дигәндәй шыкаеп, өйдән чыгып шылды.* Х.Камалов. *Әнинең кычкыруыннан шыкаеп, тиз-тиз юынам да, аннан-моннан капкалап, матаема атланып, печәнгә чыгып чабам.* Ф.Төхбәтуллин

**Шыкаеп кую** Бер мәртәбә шыкаю. *Авыздан нәҗес исе килүдән эчкән вакытта ук шыкаеп куйган идем.* Т.Нәҗмиев. *Мондый чакта саксыз сүз ычкындырырмын дип тә шыкаеп куя.* М.Вәлиев

**Шыкаеп тору** Күпмедер вакыт шыкаю; әле, хәзерге вакытта, сөйләп торганда шыкаю. *--- китмәгән икән бу беркая да. Абзар артында гына шыкаеп торган да, әнисе мал караган арада өйләренә кереп, өй астына урнашкан.* М.Мәһдиев. *– Менә бераз гына токтан идем. Булатов киләсе бугай. Шуннан шыкаеп торам әле, – дигән.* Т.Нәҗмиев

**ШЫ́К ИТҮ** *ф. к.* **шак итү**. *Шык итте Саррәләр капкасының эләкмәсе.* Ф.Әмирхан. *Ул торып басарга теләде,*

*тик, чак кына күтәрелүгә, башы белән шык итеп нәрсәгәдер бәрелде ---.* Н.Әхмәдиев

**ШЫКРАЮ** *ф. сөйл. к.* **шакыраю**. *Утын дигәнебез – кайчандыр киселгән агач төпләре. Алар шыкраеп кипкәннәр.* К.Булатова. *Көз коры килгәнлектән шыкраеп каткан үзле балчыкның бирешергә һич исәбе юк иде.* Ф.Яруллин

**ШЫКСЫЗ** *с.* 1) Төсе-бите күрексез, ямьсез; кыяфәтсез, котсыз. *Уй чуала, кызның эче бердән жу итә: Булып куйса «ире» шыксыз бер карт, Ул чагында сине ни көтә?* Н.Исәнбәт. *Бәхетсез мин, бәхетсез, ямьсез, шыксыз мин. Кызлар дөрес әйтәләр.* Н.Кәримова

2) Авыр тәэсир итә торган, күңелгә ятышсыз, иләмсез. *Әле генә шундый җылы булып, күңелле булып тоелган бүлмә Исламга кабердән дә тар булып, суык, шыксыз булып күренде.* Н.Фәттах. *Түгәрәк әгъзалары үткән дәвердәге авырлыкларны җаннары аша кичереп утырганда, Фатыйх Сәгыйтовның шыксыз тавышы тынлыкны бозды ---.* Ф.Сафин

**ШЫКСЫЗЛАНДЫРУ** *ф. йөкл. юн. к.* **шыксызлану**. *Ә рак чыннан да шулхәтле яман авыру: ул кешене кыска гына вакыт эчендә дөньядан алып кына китү түгел, --- үләр алдыннан гарипләтә, шыксызландыра, танымаслык итә.* Шәһри Казан. *Инвестор бу кече калаларны шыксызландырып, җир өстендә пар чыгарып яткан торбаларны җир астына яшерде.* Ватаным Татарстан

**Шыксызландырып җибәрү** Бераз, беркадәр шыксызландыру. *Сәлим мулланың калтырап чыккан хәлсез тавышы әле генә мәет озаткан өй эчен гүя тагын да караңгыландырып, тагын да шыксызландырып җибәрде, күңелгә шом өстәлде.* И.Сираҗи

**ШЫКСЫЗЛАНУ** *ф.* 1) Тышкы нәфислеген, матурлыгын югалту; ямьсезләнү, килбәтсезләнү, котсызлану. *[Исхак] соңгы вакытларда үзенең шулай шыксызланган булуына аптырап, ышанмыйча торды.* С.Рәфыйков. *– Басра ягына, Басра ягына чыгып ычкыныгыз! – дип --- әмер биргән чакта, болай да котсыз Рәис тагын да шыксызланган, кыргыйланган иде.* В.Имамов

2) Яме китү, шыксыз, күңелсез хәлгә килү. *Көннәр шыксызланды, берөзлексез ява торган көзге яңгырлар башланды, я көне буе сибәләп тора ---.* Р.Сәгъди. *Йорт күзгә күренеп шыксызлана: беренче каттагы панель йөзеңне кызартырлык оятсыз сүзләр белән тулды.* Р.Галиуллин. *Җәй урталарында инде дала тәмам көеп, эштән чыга. Бөтен тирә-як шыксызлана, ком төсенә керә.* И.Беляев

3) *күч.* Начар якка үзгәрү, ямьсезләнү, начараю. *Адәм баласының рухи дөньясы шыксызланган саен, тышкы кабыгы ялтырый икән.* Н.Гыйматдинова

**Шыксызлана бару** Акрынлап шыксызлану, торган саен ныграк шыксызлану. *Һава көннән-көн начарлана, шыксызлана барды.* Р.Сәгъди. *Елдан-елга тормыш катлаулана, Шыксызлана бара җир йөзе.* Г.Афзал

**Шыксызлана башлау** Акрынлап шыксызлануга табан бару. *Шактый гомер үтеп тә, чибәрлеген, күркәмлеген югалтмаган --- Зәйнәпне күргәч, гомерендә дә чибәр хатын булып саналмаган, инде шактый ук шыксызлана башлаган Маһруза бермәлгә каушап калды.* Х.Ибраһим

**Шыксызлана төшү** Берникадәр шыксызлану. *Гөлбану алдына чүгәләгән бу шыксыз абыйга карап хәйран калды. Елмайганда, тагын да шыксызлана төшә ул.* М.Хәсәнов

**Шыксызланып бетү** Тәмам, бик нык шыксызлану. *Саубуллашканда ул: «Бу эшкә килүең әйбәт булган анысы, ир кеше кулы, каты кул кирәк монда. Югыйсә китапханә --- бөтенләй таралып, шыксызланып бетте!» – диде.* Р.Вәлиев

**Шыксызланып калу** Ниндидер бер вакыйгадан соң шыксызланган хәлгә килү. *Һәрхәлдә, тирәкләр агып киткәннән соң, Назыйм озак кына үз җанының кайсыдыр почмагында бушап, шыксызланып калган урыннар сизә башлады.* Ф.Яруллин. *Менә бервакыт агачларда яфраклар коелып беткән, табигать ялангачланып, шыксызланып калган.* Г.Гыйльманов

**Шыксызланып китү** Кинәт шыксызлану. *Тирә-юнь кинәт кенә салкынаеп, шыксызланып киткәндәй булды.* Р.Вәлиев

**Шыксызланып тору** Вакытлыча шыксызлану; әле, хәзер шыксызланган хәлдә булу. *Төн буе каралып, шыксызланып торган тәрәзәләр дә таң нуры белән агара башлады.* А.Шамов

**ШЫКСЫЗЛЫК** *и.* Ямьсезлек, тупаслык; шыксыз булу сыйфаты. *Йөрәккә салкын шыксызлык килеп бәрелә.* Х.Камалов. *Баштарак Илсөяр Фатыйхка бирелгән бүлмәнең шыксызлыгына артык игътибар итмәгән иде.* Ф.Яруллин

**ШЫ́К-ШЫК** *иярт. к.* **шак-шок**. *– Нишлим соң, мин гаеплемени? – диде Талип, елардай булып, һәм аның тешләре бер-берсенә шык-шык бәрелеп куйды.* Ә.Еники. *Шык-шык... Шык-шык... – Нигә тәрәзә шакыйсың, әти?* Н.Гыйматдинова

**ШЫ́К-ШЫК ИТҮ** *ф. к.* **шак-шок итү**. *Мин дә киттем артларыннан, Шык-шык итә ботинкам.* Р.Миңнуллин. *Ул арада кемдер шык-шык итеп ишек кага башлады.* Ф.Бәйрәмова

**ШЫ́К-ШЫК КИЛҮ** *ф. к.* **шак-шок итү**. *Калтыранам, дерелдим, тешләрем бер-берсенә бәрелеп шык-шык килә: үләм бит, үләм.* М.Әмирханов. *Әтисе бик ашыга. Ашыкканын шуннан белә: Шык-шык килә кашыгы.* Г.Гыйльманов

**ШЫКЫЛДАВЫК** *и. к.* **шакылдавык**

**ШЫКЫЛДАТУ** *ф. к.* **шакылдату**. *Биек үкчәләрен шыкылдатып, сәхнәгә Нәркис чыкты ---.* М.Мәһдиев. *Аккошлар аның кулларыннан җим алалар, томшыкларын шыкылдаталар ---.* М.Хәбибуллин

**ШЫКЫЛДА́У** *ф. к.* **шакылдау**. *Тешләр тешкә бәрелеп шыкылдады.* Н.Гыйматдинова. *Коридорда, күрше бүлмәдә хатын-кызның безле үкчәләре шыкылдады.* А.Хәлим. *Өч-дүрт җирдә машинка шыкылдады.* Ф.Латыйфи

**ШЫКЫ́Л-ШЫКЫЛ** *иярт. к.* **шакыл-шокыл**. *Уртада, кашыкларын шыкыл-шыкыл китереп, Биктәш такмаклый-такмаклый бии.* И.Гази. *Чәй калагы белән шыкыл-шыкыл чәен болгата.* З.Хәким

**ШЫКЫРДАП** *рәв.* **шытырдап**. *Озакламый чокыр тирәсенә әрдәнә-әрдәнә саман кирпечләр өелде. Кояшта шыкырдап киптеләр.* И.Салахов. *Кырык икенче елның көзендә, авыл урамнарындагы баткаклар шыкырдап туңган чакта, япа-ялгыз ат яшәгән агач сарайны төнен сүтеп алып киткәннәр.* З.Зәйнуллин. *Юеш итекләр суыкка чыккач шыкырдап ката ---.* Л.Гыймадиева

**ШЫКЫРДАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **шыкырдау**

2) Шыкырдаган тавыш чыгару. *Ул күзләрен йомды, сызланудан йөзе газаплы тартышты, тешләрен шыкырдатты, ләкин ыңгырашмады.* Ф.Садриев

**Шыкырдата башлау** Шыкырдатырга тотыну. *Менә берзаман, кояш югарырак күтәрелгәч, өйалды ишеген шыкырдата башлыйлар.* Г.Бәширов. *Кулыма эләгү белән шыкырдата башладым ул шикәрне.* К.Миңлебаев

**Шыкырдатып алу** Бераз яки бер тапкыр шыкырдату

**Шыкырдатып җибәрү** Кинәт шыкырдату, көтмәгәндә шыкырдату

**Шыкырдатып кую** Бер тапкыр шыкырдату. *Тик шунда ул тешләрен шыкырдатып куйды, аның күзләре кысылды.* Г.Бәширов

**Шыкырдатып тору** Даими яки әледән-әле шыкырдату; әле, хәзер шыкырдату

**ШЫКЫРДАТЫП** *рәв. к.* **шытырдатып** (*1 мәгъ.*). *Кичтән шыкырдатып катыра да иртәнгә җепши, төшкә салкын тагын куырып ала.* М.Хуҗин. *Таң атканчы яңгыры да, кары да явып китәргә мөмкин, көтмәгәндә генә шыкырдатып туңдырып та куя.* К.Кәримов

**ШЫКЫРДА́У** *ф.* 1) Тимер, таш һ.б.ш. каты нәрсәләр бер-берсенә ышкылып киткәндә өзек-өзек тонык тавыш чыгу; шыкыр-шыкыр итү. *Банкалар шыксыз тавыш чыгарып шыкырдады.* Ә.Хәсәнов. *Мотыйгуллин тагын бераз тыңлап торды: – Тимер шыкырдый димме?.. – Шуңа охшаган шул.* З.Фәтхетдинов. *Политрук гөрелдәп һәм шыкырдап танклар якынлашып килгән куаклыклардан күзен алмый.* И.Кудинов

2) Ачу, усаллык яки башка хистән яисә йокы аралаш тешләрне каты кысып бер-беренә ышку, шыгырдаган тавыш чыгару. *Аның йөзе кыйшайган, күзләре атылып чыгарга җитешкән тешләре шыкырдый иде.* Г.Бәширов

3) Шыкыр-шыкыр итүне хәтерләткән тавыш чыгару (саескан тур.). *Сартаков, --- саескан шыкырдаган төсле шыкырдап чыга торган тавышлы --- абзый, миңа бер дә гаҗәпләнмичә, йөзенә гримаса чыгармыйча: – Кызлар янына барырга карт инде мин, коллега, – диде.* Г.Ахунов. *Саескан, сиртмә койрыгын селкетә-селкетә, нидер шыкырдыйшыкырдый очып китә.* М.Хәбибуллин

4) *к.* **шыгырдау** (*3 мәгъ.*). *Син бит тимер тәртип урнаштырдың кадрлар арасында. Шыкырдап кара. --- Совхоз директоры Галимҗанов бер генә каршы сүз әйтте. Бер ай эчендә – выжт!* Ф.Садриев

◊ **Шыкырдап торган** 1) *к.* **шыгырдап торган**. *Минем хәтеремдә: тышта шыкырдап торган каһәрле кыш иде.* Ш.Камал. *Шыкырдап торган йөзлекне күкеле сәгатькә алыштыргач Нәгыйматтәй, сдачасын да санарга онытты.* К.Кәримов. *Өр-яңа билетның шыкырдап торган битенә корыч каләм очын кара тушька манып, таныш түгел кешенең --- исеме язылa.* М.Галиев; 2) *к.* **шыңгырдап торган**. *Хан сараедай шыкырдап торган нарат бүрәнәләрдән йортын да салдык ---.* Н.Хәсәнов

**Шыкырдап алу** Бераз яки бер тапкыр шыкырдау. *Бакчага кергәндә, ул юри саескан булып шыкырдап ала.* Көмеш кыңгырау

**Шыкырдап кую** Бер тапкыр шыкырдаган тавыш чыгару. *Картның йөзе агарып китте, ачудан тешләре шыкырдап куйды.* С.Сабиров. *Кинәт саескан шыкырдап куйды.* Ә.Маликов

**Шыкырдап тору** Өзлексез яки әледән-әле шыкырдау; әле, хәзер шыкырдау. *Эленеп торган кием-салымнарны карыйм: шыкырдап торалар, ялтырыйлар, төсләре гадәттән тыш җете, исемнәре ят: нейлон, кримплен, джерсилар...* М.Галиев

**Шыкырдый башлау** Шыкырдарга тотыну. *Җилнең мондый да тәрбиясез кыланышыннан тәмам туеп, теш арасында тарихи ком бөртекләре шыкырдый башлагач, Сергей Михалков иптәш Ахуновны читкәрәк алып китә ---.* М.Галиев

**ШЫКЫ́Р-ШЫКЫР** *иярт.* 1) Тимер, таш һ.б.ш. каты нәрсәләр бер-берсенә кат-кат ышкылганда чыккан өзек-өзек тонык тавышны белдерә. *Эчкән чагында тешләре калайга шыкыр-шыкыр бәрелгәләде.* Э.Касыймов

2) Шуңа охшаш саескан кычкырган тавышны белдерә

**ШЫКЫ́Р-ШЫКЫР ИТҮ** *ф.* Шыкыр-шыкыр кебек тавыш чыгару, шыкырдау. *Бервакыт аның колагына әллә штукатурка, әллә кирпеч арасын кыргандагы шыкыр-шыкыр иткән тавыш чалына башлады.* Ә.Дусайлы

**ШЫКЫ́Р-ШЫКЫР КИЛҮ** *ф. к.* **шыкыр-шыкыр итү**. *[Тавыш] шактый гына шыкыр-шыкыр килә дә, бераз тынып торгач, тагын шыкырдый башлый.* Ә.Дусайлы

**ШЫКЫ́-ШЫКЫ** *иярт. к.* **шакшок**. *Салкын кружканы шыкы-шыкы китереп тешенә бәреп ятканда, Былбылниса аның кружкасын тартып ала ---.* М.Мәһдиев. *Хәйри имән бармагы белән шыкы-шыкы өстәлне төйде: – Сез мине юләргә санамагыз.* Ф.Садриев. *Аста, залда, җыештыручылар эшкә керешкән, --- шыкы-шыкы басып кызлар үткәли ---.* Р.Кәрами

**ШЫКЫ́-ШЫКЫ ИТҮ** *ф. к.* **шакшок итү**. *Тимер шеш белән җиргә төртеп карадың исә, шыкы-шыкы иткән тавыш килә, ди.* Н.Фәттах

**ШЫКЫ́-ШЫКЫ КИЛҮ** *ф. к.* **шакшок итү**. *Шыкы-шыкы килеп, вагоннар юлдан юлга күчтеләр, акрынайдылар.* М.Мәһдиев. *Инде аның теше тешкә бәрелеп шыкы-шыкы килә, куллары туңса да, ул башыннан һәм аркасыннан тир агуын сизә.* Ф.Садриев

**ШЫЛАН** *и. бот.* Наратбашчалар семьялыгыннан туры сабаклы, йомшак ылыссыман яфраклы, сазламык җирләрдә үсә торган күпьеллык споралы үсемлек; *русчасы:* **хвощ иловатый**. *Кыяк, камыш, шылан шикелле саз үсемлекләре --- сәгать саен өскә үрмәлиләр төсле.* Ш.Маннур

**ШЫЛДЫРАВЫК** *и.* 1) *диал. к.* **шөлдерут**. *Шылдыравык (җәйге шөлдерут) көпшәле ачык сары төстәге эре ялгыз чәчәкләре – башаксыман чук чәчәк төркеме хасил итәләр.* Агулы үсемлекләр

2) Селкеткәндә, кагылганда эчендәге вак нәрсәләр шалтырый торган куыш эчле балалар уенчыгы; шалтыравык. *Ата-анасы аңарга балалар өчен ясалган курчак вә уенчыклардан һичбер нәрсә алып бирмәсәләр дә, ул шылдыравыктан башка базар уенчыгын күрмәсә дә, бер дә аптырамый иде.* Г.Ибраһимов

3) *к.* **кыңгырау** (*3 мәгъ.*). *(Шәңгәрәй ишекне ача, ишектә Гариф.) [Гариф:] Аз гына да ихтирамың юк кешегә. Шылдыравык төймәсен баскан килеш шунда – бусагада үлеп калсам.* С.Шәкүров

**ШЫЛДЫРА́У** *ф. к.* **шалтырау**. *«Абушай җыры» дип аталган тарихи җырдагы: Абушай аягында койма богау, Вак-вак атласа да шылдырый, дигән юлларны моңа мисал итеп китерергә булай.* Н.Фәттах. *Хатынның җанын сөенеч билә. Шушы сәер кунак аркасында капка келәсе шылдырамый. Хәер, элек тә аңа бик килмәделәр.* Н.Гыйматдинова

◊ **Шылдырап торган** *к.* **шыңгырдап торган**. *Шылдырап торган нарат бүрәнәләрдән салынган ике катлы йорт масаеп тора.* Т.Галиуллин

**ШЫЛДЫ́Р-БЫЛДЫР** *с.* **1.** 1) Начар, сыйфатсыз, ни җитте шундый

2) Түбән әхлаклы, уңай сыйфатлары аз булган. *Диләрә – бүгенге шылдырбылдыр заманның шәһәрдә туган баласы.* Т.Миңнуллин

3) Дәрәҗә, абруй ягыннан түбән булган, ихтирамга лаек булмаган. *Кәрим Тинчурин ул Кариевтан кала иң олы сәнгатьче иде. Шылдыр-былдыр гына*

*түгел, төптән, тирәннән уйлап гамәл кылучы олы шәхес иде ул.* Р.Батулла

**2.** *и. мәгъ.* Сыйфатсыз, начар, аннан-моннан гына эшләнгән, килде-китте нәрсә. *Танылган, хәтта күренекле музыкант та чыгасы иде миннән. Бәлки, композитор да булган булыр идем. Бүгенге «йолдызлар» язган шылдыр-былдырны мин хәзер дә яза алам.* Т.Миңнуллин

**ШЫЛДЫРЛЫ** *с. к.* **шөлдерле**. *Еракта, шылдырлы гармунда уйнап, клоунның халык җыйганы ишетелә.* Т.Гыйззәт

**ШЫЛДЫРМА** *и.* Туку станында көре хәрәкәтен җиңеләйтә торган блоксыман җайланма, чыгыр. *Туку станында көре аса торган шылдырмалар була*

**ШЫЛДЫРУ** *ф.* 1) Нәрсәне дә булса этеп, шудырып, бер урыннан икенче урынга күчерү. *Мин түзмәдем, ишекне бөтен көчемә шылдырып ачып җибәрдем.* Ә.Еники. *Әфтах яшьләргә комсомол исеменнән кыска гына нотык сөйләде, шуннан без чаршауны шылдырып, уйный башладык.* Мирас

2) *күч. гади с.* Яшертен сату, сатып җибәрү. *[Миңлебикә:] Сиңа киңәш итми сатмам. Шылдырырмын, Алла насыйп итсә.* Ә.Фәйзи. *Ярый әле, болыннан печән ташырга тотынгач, койрыгына баскандай иттек, алай да шушындый кытлык елны никадәр печәнне сулга шылдырган – чуртым белә.* Э.Касыймов

3) *күч.* Качырып озату, еракка җибәреп яшерү. *Ә ике малайны әкрен генә партизаннарга шылдырган идем.* Г.Гобәй. *Гафур намазлык өстендә уңгасулга борыла да: --- «Әссәламегайкем вә Фәттахулла, авызыңны ачып утырма, атны шылдыр, Аллаһе әкбәр», – дип, догасын дәвам итә.* Я.Зәнкиев

4) Урлау

5) *күч.* Шудыру, куу. *Шуның өчен әйтәм: без бик зур башлап кечкенәсеннән калмыйк, дим! Безне тегеннән, банктан шылдырмасыннар, дим!* Г.Исхакый

**Шылдыра башлау** Шылдырырга тотыну

**Шылдыра тору** Һаман шылдыру. *Качкыннар төялгән пароходлар Англиягә, Франциягә, Төркиягә шылдыра тордылар.* Н.Дәүли

**Шылдырып бетерү** Барысын да шылдыру

**Шылдырып җибәрү** Кинәт шылдыру. *Тиз генә чуар халатын киеп, тәрәзәнең рәшәткәсен шылдырып җибәрде.* Ә.Еники

**Шылдырып кую** Шылдырган хәлгә китерү; тиз арада яки алдан шылдыру. *Капка ябыла, аркылы агачын яңадан шылдырып куялар, шуннан бермәлгә ишегалды да тынып кала.* Ә.Еники

**Шылдырып тору** Һәрвакыт, гел шылдыру; әледән-әле шылдыру

**ШЫЛДЫ́Р-ШЫЛДЫР** *иярт.* 1) *к.* **чылтыр-чылтыр**. *Кайда карасаң да, ямь-яшел агач белән капланган өлкән вә биек-биек таулар, урманнар, карагайлар, акланнар, җимешле агачлар арасыннан, таш эченнән шылдыр-шылдыр агып яткан көмеш кебек елгалар адәмнең мәхәббәтен җәлеп итә...* Г.Ибраһимов

2) *к.* **шалтыр-шолтыр**. --- *кылычларын, шпорларын шылдыр-шылдыр китереп, бер төркем казаклар килеп керде.* И.Салахов. *Күрәм, ул бүген бик ыспай итеп киенеп җибәргән. Күлмәгенең итәкләре нindидер бөҗралар белән урап алган шикелле. Муенсасы шылдыр-шылдыр килә.* Н.Дәүли. *Сыкрый ишек. Әни ачса – Шылдыр-шылдыр Җырлый ишек.* Р.Шәрипова

**ШЫЛТ** *иярт.* **1.** Әйберләр берберенә җиңелчә генә бәрелгәндә чыккан тонык кына, сүрән генә берәр төрле тавышны белдерә. *Кайда бака? Тап, тап, тап! Шылт, шылт, томшык ачкалап, Эзләп йөри ач тамак.* Г.Әпсәләмов. *Качкыннар шылт та шылт, мылтыклар шарт та шорт!..* Г.Мөхәммәтшин. *Газинур абыйның фотоаппараты минут тик тормый: шылт та шылт.* Сөембикә

**2.** *рәв. мәгъ.* Бик тиз, тиз генә; кинәт, капыл; җиңел генә, ансат кына. *Куенныннан монтировка чыгарып ишекне шылт кына итеп ача.* Ф.Яруллин. *Сәет танышының сәркатибенә, үзенең кем икәнен әйтмичә генә, «шәхси мәсьәлә белән» дип, шылт кына кереп китмәкче иде ---.* Т.Галиуллин

**3.** *хәб. функ.* Эшнең, хәрәкәтнең бик тиз вакыт эчендә эшләнүен белдерә; шалт. *Монда чыгып китәр алдыннан: – Син анда авызыңны ачып изелеп утырма, – диделәр. – Югары өйдә дөпдөп идәнгә типтеләрме, шылт идән астына! Белдеңме?* Г.Бәширов

◊ **Шылт итеп** Кисәк, кинәт, кылт итеп. *Казанга килеп 5 нче трамвайга утыруга, шылт итеп Гөлхәбирә искә төште.* А.Хәсәнов. *Кинәт шылт итеп хәтеренә төште аның: төш, бүген күргән сәер төш – баеп баручы кояшны куып атта чаба да чаба, чаба да чаба ул.* Х.Мөдәррисова. *Шылт иткән тавыш та юк Тулы тынлык. Әледән-әле торып, ишектән башны тыгып карыйм – дегет шикелле кара төн, үлек дөнья, шылт иткән тавыш та юк.* Ә.Еники. *Тирә-якта шылт иткән тавыш юк.* А.Гыйләҗев. **Шылт тавыш юк** *к.* **шылт иткән тавыш та юк**. *Шылт тавыш юк, Хәтта кошлар очмый.* М.Шабаев. **Шылт та итми** *к.* **шылт та итмичә**. *Әллә аларның шылт та итми утырулары ошады, әллә санаулы минутларны тулырак файдаланасым килдеме – рәхәтләндем мин, Тубыл укучыларын сүз белән сыйлап.* Т.Әйди. **Шылт та итмичә** Бернинди тавыш чыгармый, тавыш-тынсыз гына, тулы тынлыкны саклап. *Мондый концертның бу авыл тарихында беренче генә булуыдыр, ахрысы, җыелган халык, хәтта тиктормас бала-чага да, биһуш булып, шылт та итмичә тыңладылар.* Ә.Еники. **Шылт та юк** *к.* **шылт иткән тавыш та юк**. 1) *Төн... Тирә-як шундый тын... Шылт та юк...* У.Шекспир; 2) Гауга, җәнҗал, тавыш булмау турында. *Телеңә тилчә чыккыры, цифрлар үтәлгән иде, шылт та юк иде...* Ф.Сафин

**ШЫ́ЛТ ИТҮ** *ф.* Тонык кына, сүрән генә берәр төрле тавыш чыгару. *Фатыйх --- тыныч, тавышсыз йоклый, әмма аның йокысы бик зирәк, аз гына шылт иттеңме – ул уяна.* М.Мәһдиев. *Шунда капканың келәсе шылт итте ---.* Н.Гыйматдинова

**ШЫЛТЫР** I *иярт.* **1.** *к.* **шалтыр**. *Телефон шылтыр-ррр итсә, йөгереп барабыз да кулга телефон трубкасын алабыз.* Ә.Бикчәнтәева

**2.** *с. мәгъ. күч.* Мактану, шапырыну билгеләрен чагылдырган; буш. *Шәйбәк мулласының елтыр күзле һәм «шылтыр» сүзле кызы Заһидә жикет кесәсеннән карта чыгарды да өстәлгә сибеп ташлады.* Ш.Маннур

**ШЫЛТЫР** II *и.* Умырткалы хайваннарда женси теләк. *Җир бит бия төсле: шылтыр булдымы – чаптырырга ашык, ә шул вакыт үттеме – айгырга төкер.* Ш.Камал. --- *аерым үсемлекләрнең чәчәкләрендә һәм җимешләрендә холестеролдан барлыкка килгән хайван женес гормоннарына охшаган сыекчасыман матдәләр – фитоэстрогеннар табылган. Аларның хайван организмында шылтыр китерү, женси теләк тудыру һәм теләкне саклау үзлекләре тудыра торган матдәләр булуы ачыклана.* Агулы үсемлекләр

**ШЫЛТЫРАВЫК** *и.* 1) *диал. к.* **шөлдерут**

2) *к.* **шылдыравык** (*2 мәгъ.*). *Бала арбасында төрле төстәге шылтыравыклар таралып ята* // Гомумән балалар уенчыгы

3) Юк-бар нәрсә, кирәкле-кирәксез, әһәмиятсез нәрсәләр. *Гомердә адәм күрмәгән, колак ишетмәгән әллә нинди шылтыравык төяп кайткан бу.* С.Сабиров

**ШЫЛТЫРАТУ** *ф. сөйл. к.* **шалтырату**. *Зөһрә апа иртән --- милициягә китте, телефон-автоматтан врачка шылтыратты.* А.Гыйләҗев. – *Баш өсте, гөләбем, йөгерәм! – диде Газинур, үзе, чиләкләр шылтыратып, коега чапты*. Г.Әпсәләмов

**ШЫЛТЫРА́У** *ф. к.* **шалтырау**. *Кесәләрендә акча шылтырый кеби хис итәләр.* Г.Тукай. *Капка келәсе шылтырап төште*. Г.Ахунов. *Аннан кемнәрнеңдер кычкырып сөйләшкәне, табак-савыт шылтыраганы ишетелде.* Н.Фәттах

◊ **Шылтырап тору** *к.* **шалтырап тору**. *Сездән яшерергә теләмим, хәл авыр. Келәт буралары шылтырап тора, колхоз амбарларында да шул хәл.* Ә.Баян. *[Талипның] күкрәге шиңеп төшкән, киемнәре астында сөякләре генә шылтырап тора кебек.* Н.Дәүли

**ШЫЛТЫ́Р-МЫЛТЫР** *иярт. к.* **шалтыр-шолтыр**. *Яшьләргә күп кесәле, шылтыр-мылтыр тимер йозаклары ялтырап тора торган куртка ошый.* Т.Әйди. *И-и-и, шунда Арба бер кеткелдәп, --- тугымнары күчәрләрендәге майларын чыкылдатып, чылбырларын шылтыр-мылтыр иттереп, тәртәләрен киереп, тирән итеп --- бер сулыш алган ---.* Сабантуй

**ШЫЛТЫ́Р-ПЫЛТЫР** *иярт.* **1.** *к.* **шалтыр-шолтыр**. *Юньлерәк юлга тап булуга, элдертәсе килә башлый – калтыр-колтыр, шылтыр-пылтыр күпме барырга мөмкин – арыта!* Шәһри Казан

**2.** *с. мәгъ.* Начар, сыйфатсыз, килдекитте. *СССР таркалганнан соң, шылтыр-пылтыр, ягъни бик җиңел җырларга күчтек.* Мәдәни җомга

**3.** *и. мәгъ. к.* **шылдыр-былдыр 2.** (*1 мәгъ.*). *Әмма халык мәзәктән, шылтыр-пылтырдан туйды.* Акчарлак

**ШЫЛТЫ́Р-ШЫЛТЫР** *иярт. к.* **шалтыр-шолтыр**. *Шылтыр-шылтыр юлдин арбалар китәләр.* Г.Тукай. *Зәңгәр бизәкле көянтә кызның иңбашыннан шуып төште, сыңар чиләк шылтыр-шылтыр ярдан түбән тәгәрәде.* Г.Әдһәмова

**ШЫЛТЫ́Р-ШЫЛТЫР ИТҮ** *ф. к.* **шалтыр-шолтыр итү**. *Дәрвазәгә якын килгәндә, шылтыр-шылтыр итеп дәрвазәнең йозагын ачты да дәрвазәне ике тарафка ачып җибәрде ---.* Дастан

**ШЫЛТЫ́Р-ШЫЛТЫР КИЛҮ** *ф. к.* **шалтыр-шолтыр итү**. *Ә алда Шәймәрдан бабай биясенең муенындагы кечкенә кыңгырау шылтыр-шылтыр килгән була.* Ә.Еники. *Мине оныттыгыз дигәндәй, шылтыр-шылтыр килеп, пар чыгу өчен куелган нәни түбәтәйләр сикерешә.* Р.Мөхәммәдиев

**ШЫЛУ** *ф. сөйл.* Сиздермичә генә китү, бик тиз качып китү; ычкыну, таю. *--- егет, атлыларны күрү белән, --- башта куаклар артына поса, аннары, текә яр астына сикереп, су буйлатып кына авылга шыла.* М.Хәсәнов. *Ул бердәнбер сәркатип хатыннан гына шүрли, коридорга Мәйсәрәнең шәүләсе төшсә дә, бүлмәсенә шыла иде.* Н.Гыйматдинова

**ШЫМ** *рәв.* 1) Тып-тыныч, бер хәрәкәт тә ясамый, кымшанмыйча. *Моңа кадәр, кузгалырга да куркып, бер урында шым торган дүрт егет аның артыннан иярде.* Р.Вәлиев. *Фаяз --- җыерчыклы йөзен картузы белән күләгәләгән Гаделшаны күргәч шым булды.* М.Маликова

2) Бер тавыш та чыгармыйча, шауламыйча, тавышсыз гына, шыпырт кына. *Болында, өй эчендә меңләгән ирләр, илме, яумы буласын белмичә, тынnарын кысып, шым гына утыра бирделәр.* Н.Фәттах. *Тешсез авызлардан сүз чыкмады, хатыннар иртәгә тагын Зәйнәп катына баш орып киләселәрен чамалап тындылар, шым гына таралдылар.* А.Гыйләҗев

◊ **Шым булу** Шүрләп, тыелып тору, тавыш-тын чыгармау, койрыкны кысу. *[Мостафин:] «Сарылма!» – дип кенә әйтте, һәм ул моны шундый итеп әйтте ки, Нажҗия берьюлы шым булып калды.* Ә.Еники. *Хатыны Инга ---: – Ташла, тиеш түгелне сайрап утырасың, – диде, төксе генә карап. Фогельсон шым булды, ничектер, утырган җирендә сеңеп киткәндәй итте.* Х.Камалов.
**Шым гына** Кешегә сиздермичә, качып-посып кына. – *Шым гына барып, каршыларына чыгасым калган, – диде Сәлим үз-үзенә.* Г.Гобәй

**ШЫМАЙТУ** *ф. сөйл. к.* **шомрайту**. *[С.Рәмиев] көчәнеп тавышын да күтәрми, күрер күзгә тайчандырырлык хәрәкәт тә ясамый, шулай да колакны шымайтып утырырга мәҗбүр итә.* И.Рәмиев. *«Монысы әле баласы, алда булыр анасы». Егетләр дәррәү колакларын шымайттылар.* Г.Рәхим

**ШЫМАЮ** *ф. сир. к.* **шым булу**. *Егетләр Тимерне күрүгә бераз шымаеп, тынып калдылар.* Г.Рәхим. – *Сез, юеш борыннар, табигать байлыгыннан явызларча файдаланасыз, сез – браконьерлар, – диде беркөнне Шакир, бот хәтле малайларны өркетеп. «Браконьерлар» шымайды.* Н.Гыйматдинова

**Шымаеп калу** *к.* **шымып калу**. *Больницага авыру янына килгән кешеләр һәрвакыт кинәт шымаеп калалар.* Г.Рәхим

**ШЫМУ** *ф. сир. к.* **шым булу**. *[Мәче] аш өйдән килә шымып, Күзләрен тиз-тиз йомып.* Дәрдемәнд. *Башлар түбән таба иелделәр, машиналар шымды, Тын калды.* Һ.Такташ

**Шымып калу** Кинәт шымайган хәлгә килү. *Шәһәрнең пычрак урамнары, фәкыйрь йортлары айның көмештәй яктысы астында тынып, шымып калдылар*. М.Галәү. *Тәхет Хансарай әтрафындагы гаугалар бетте, астыртын эш йөртүчеләр дә койрыкларын кысып, шымып калдылар.* Р.Батулла

**Шымып тору** Вакытлыча шыму; билгеле бер вакытка шыму. *Бу тәңгәлдә мин ялгызак түгел, Чал табигать – тиңсез көндәшче: «Һәрбер кузәнәгем – тере шигырь, Син шымып тор, шагыйрь!» – димәкче.* Р.Идиятуллин

**ШЫМЧЫ** *и.* 1) Яшерен полиция агенты, җасус. *Кавиның талантыннан көнләшеп яшәгән каләмдәшләре арасында имеш-мимеш гайбәт тарала башлый: «НКВД кулында утырганда, күпләрне саткан ул! Шуңа күрә исән калган, шунлыктан безнең арага шымчы итеп чыгарганнар инде».* З.Зәйнуллин

2) Берәр кешене күзәтүче, аның һәрбер хәрәкәтен тикшереп, тиешле җиргә яки кешегә җиткереп торучы. *Татар комитетында алар даими күзәтү астында булалар. Адым саен шымчы, кая карама фашист ярдәмчеләре.* Р.Мостафин. *Шымчы бит ул кемнәрнеңдер кулында корал гына. Ул ни сөйләмәс тә нәрсә язмас. Төп хикмәт – аның сүзен тыңлап, язганнарын укыган кешеләрдә.* М.Маликова

3) *к.* **шпион** (*1 мәгъ.*). *[Саҗидә]: --- Зифабанулары аклар ягыннан шымчы булып кайткан бит.* Г.Камал. *Ул, эшне озакка сузмас өчен, кесәсеннән пычак чыгарып, шунда ук немецка ташланды. Ләкин ул аңа кадамады,*

*муеныннан эләктереп, чокырдан өскә өстерәде. Шымчы гырлап тыпырчына иде.* А.Расих

**ШЫМЧЫЛАНУ** *ф.* Шымчы булып йөрү, шымчыга әйләнү. *Ул-бу булмагае дип шикләнәбез, ышанмыйбыз, аларның күңелендә гел яктылык, сафлык, нәфислек кенә туган минутларын артык төпченүебез, шымчылануыбыз белән каралтабыз.* Л.Ихсанова. *Баштанаяк утлы корал белән коралланган полк воеводасы князь Афанасий Лычеицын гаскәре кирәк икән, сугышырга, кирәк икән, шымчыланырга, мөмкинлек чыкса, ике дә уйламыйча, Күчем ханның үзен дә үтерергә тиешләр иде.* Ф.Бәйрәмова

**Шымчыланып тору** Һәрвакыт, гел, әледән-әле шымчылану. – *Хватит диләр сиңа, хватит! – дип пырдымсызланды Камил, барын да онытып. – Ни минуты покоя! Үзең ялга дип кайтардың, үзең гел шымчыланып торасың!* Ф.Бәйрәмова

**ШЫМЧЫЛА́У** *ф.* Шымчы сыйфатында кемнеңдер артыннан күзәтеп йөрү. *Берәүнең бер атымы яки башка төрле нәрсәсеме җуелса, Мүки бабага килеп, Мүки баба кем угырлаганын шымчылап белеп, ул угырланган нәрсәне табып чыгарадыр икән.* К.Насыйри

**Шымчылап карау** Шымчыларга тырышу. *Кеше дә яллап, үзем дә артыңнан шымчылап карадым.* Ф.Яхин

**Шымчылап йөрү** Озак вакыт дәвамында шымчылау; даими, гел шымчылау. *Алай булгач, мине тикшереп, шымчылап йөрмәгез.* Г.Каюмов. – *Нигә минем арттан шымчылап йөрисең, башка эшең юкмы әллә? – дип кычкырды Наил, ачуланып.* Г.Исхакова

**ШЫМЧЫЛЫК** *и.* Шымчы хәле; шымчы шөгыле. *Николай Ильминскийның шымчылык хезмәте яшьли үк башланган.* А.Тимергалин. *Мин алар артыннан шымчылык итеп йөрмәгән ләбаса!* В.Нуруллин

**ШЫМЫКЫЙ** *с.* 1) Шым гына яшәүче, аралашмаучан, кешеләрдән аерылып яшәгән, үз эченә бикләнгән, йомыкый. *Күрше авылның бер шымыкый гына кызына өйләнде.* К.Кара

2) Астыртын, мыштым. *Бүлмәдә ялгызы гына калгач, ул аты-юлы белән сүгенеп куйды: «Вәт шымыкый! Менә ышан син аңа», – дип, әрле-бирле йөрде ул бүлмәсендә.* Ф.Садриев

**ШЫМЫТЫР** *хәб. сүз сөйл.* **1.** Бернәрсә дә юк, коры, буш. *Тик аны төрле төрле ризык белән сыйлыйсың, ә миңа – шымытыр.* Ә.Хәсәнов. *Беркөн баш бик чатнагач, кибеткә кергән идем, шымытыр – берни юк: ни келәе, ни чебен даруы, дезодаранны әйтмим дә инде.* Н.Әхмәдиев

**2.** *и. мәгъ.* Һичнәрсә, берни, бернәрсә. *Әлмәттә дә шул нефтьтән башка шымытыр да юк икән.* А.Гыйләҗев. *Кайда эшләсә, шунда хезмәт тәртибен бозган, социализм төзелешенә таяк тыгып йөргән икән ул. Димәк, белешмә урынына да шымытыр гына сиңа!* Т.Әйди

**ШЫНА** *и. фар. диал.* Утын яра торган юкә чөй. *Шымчы шына кагарга оста булыр.* Мәкаль

**ШЫҢГЫР** *иярт.* Тонык кына калын тавыш белән яңгырауны белдерә. *--- утын түмәркәсе, шыңгырдап, урталай ярыла да, сызгырып, ике якка оча. Шыңгыр да шыңгыр килеп, шул арада бер түмәркә, ике, өч... түмәркә вакланды.* Г.Бәширов

**ШЫҢГЫРАВЫК** *и. диал.* **1.** Яңгыравык, кайтаваз кебек яңгырап торган тавыш. *[Бу музыка] көйсез-моңсыз шыңгыравык булып яңгырый иде.* Ш.Маннур

**2.** *с. мәгъ.* Тыгылган, тыңкыш. *Ләкин барган саен бер үк «кәтүк консультант»ка туры килә, ә ул --- өстәл артыннан шыңгыравык борынын гына күрсәтеп, бер үк төрле җавапны шыңгырата бирә иде: «Шигырьләрегез батардай түгел, энем!».* Ш.Маннур

**ШЫҢГЫРА́У** *ф. диал.* 1) Тонык кына калын тавыш белән яңгырау, шаңгырау. *Без үттек шулай, ташкын булып, Шыңгырап калды безнең чуен җыр.* Н.Исәнбәт. *Шыңгырасын шулай урман буйлары.* Х.Кәрим

2) Көчле матур аһәңле тавыш чыгару; яңгырау. *Шулвакыт нәкъ карт мөәззиннәр азаны яңгырый, Нәкъ Фараби хәзрәте таушы гөрелди, шыңгырый.* Ш.Бабич. *Туташның күз карашларында әллә нинди бер җазбият бар, матур тавышы шыңгырап чыга иде.* Г.Тукай

3) Чеңгелдәү, зыңлау. *Медиатор тоткан кулы гаҗәп бер сизгерлек һәм саклык белән хәрәкәтләнә. Шул сәбәпле кыллар табигый, аһәң белән, нәфис шыңгырыйлар.* С.Кудаш

4) Сузынкы, әрнүле авазлар чыгару, иңрәү, ыңгырашу. *Извозчик килүгә, ул, ашыга-ашыга, файтунга менеп салынган иде – иске арба, әллә нинди ыңгырашкан тавышлар биреп, шыңгырап китте.* Ш.Камал

5) *күч. туп.* Лыгырдау; кирәкмәгәнне, сөйләргә ярамаганны сөйләү. – *Син, Шәңгәрәй абзый, юкны шыңгырап маташма!* Г.Ибраһимов

◊ **Шыңгырап торган** 1) Буш, бернәрсәсез яки бер кешесез; шәрә. *Шыңгырап торган буш урамнардан Муса шәһәрнең үз кешесе кебек атлап барды.* Ш.Маннур; 2) Билгеле булган, киң таралган (исем, дан һ.б. тур.). *Бу училищега культура ягыннан шактый алда торган Бүздәк авылыннан гына түгел, башка авыллардан да яшүсмерләр килеп укыды. Хәзер бу авылның шыңгырап торган училищесы да, тулай торагы да, каретниклары да, нигезе дә калмаган.* Г.Кашшаф; 3) *к.* **шыңгырдап торган**. *Балтачылар, агачларның --- иң төзләрен генә аударып, шыңгырап торган бүрәнәләрдән, бер ай дигәндә, өч бура бурыйлар.* А.Хәлим

**Шыңгырап алу** Берникадәр вакыт шыңгырау. *Балта чапкан саен, бүрәнәләр шыңгырап ала.* Ш.Маннур

**Шыңгырап китү** Кинәт шыңгырау. *Зур пыяладан торган өлгеләр шыңгырап китте.* Г.Тукай. *Алар --- тылсымлы бер мандолина сатып алганнар. Кулга тоту белән шыңгырап китә.* С.Кудаш

**Шыңгырап тору** Әле, хәзер, сөйләү моментында шыңгырау. *Дәрес булмаган көннәрдә мәдрәсә бер музыка мәктәбенә охшап шыңгырап тора.* Г.Тукай. *Кайчак башта кырык төрле уй йөри. Әллә ниләр эшлисе килә. Ә менә уйлый башласаң, берни дә килеп чыкмый. Сизәсең, күңел эче буш мичкә шикелле. Шыңгырап тора.* Г.Бәширов

**ШЫҢГЫРДАП** *рәв. к.* **шытырдап**. *Рушан, әнисенең шыңгырдап каткан кыска сырмасына борынын төртеп, салкынны да сизмичә, кычкырып елый башлады.* Р.Мирхәйдәров

**ШЫҢГЫРДАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **шыңгырдау** (*1 мәгъ.*). *Аны типкәләп чыгарган соңында, ничә минутлар театр ут чыккан кебек кайнады, тик бик озак шыңгырдатканнан соң гына, рәис, мәҗлестә тәртипне торгызып, хатибка сүзен дәвам итәргә мөмкин булды.* Г.Ибраһимов

2) Яңгырату, яңгыраш, кайтаваз тудыру. *Урман эчен шыңгырдата бер сандугач.* Г.Тукай. *Дала тавышлары чыгарып шыңгырдатып җырлавы, --- һәр сүзнең ямен-тәмен татып сөйләшүе, башка күркәм сыйфатлары аны болын чәчәкләре арасында гына үскән илаһи*

*бер гүзәл зат итеп күрсәтә.* С.Поварисов. *Ул ара да булмады, кемдер, гаҗәп бер нәфислек белән шыңгырдатып, мандолина уйнап җибәрде.* С.Кудаш

3) Шыгыр-шыгыр иткән тавыш чыгару, шыгырдату. *Һәм ул, шыңгырдатып, мәктәп-мәчетнең Октябрь борылышына кадәр үк эшләнгән таза, имән ишеген ябып куйды.* М.Мәһдиев. *Бәрхетне алып, кадерләп кенә чиста яулыкка төйнәде һәм, шыңгырдатып, почмактагы олы сандыкны ачты.* М.Галиев

4) Шалтыр-шолтыр китерү, шалтырату. *Капкалар, кибетләр ачыла, кызкыркын, чиләк шыңгырдатып, фонтанга суга чыга...* Ф.Хөсни. *Торды, арты белән баскан килеш төссез сары чалбарын күтәрде, озаклап рәтләнде, аннан, комганын шыңгырдатып, кулын юды, муеныннан сөлгесен алып кулларын сөртте.* М.Мәһдиев. *Капкачын шыңгырдата-шыңгырдата, плитә өстендә чәйнек кайный ---.* Р.Мирхәйдәров

5) *күч. к.* **шыгырдату** (*3 мәгъ.*). *Район смотрларында җырлап бүләк тә алганы бар, тальянны да шыңгырдата белә иде ул.* М.Галиев. *Ишәк скрипкасын тарта, Маймыл мандолинасын чиертә, Кәҗә контрабасны шыңгырдата, тик музыка гына чыкмый.* Х.Ибраһим // Тавышын артык көчле чыгармыйча, әкрен генә уйнау. *Ләкин Рәмис берни күрми, башын гармун күрегенә терәп, шыңгырдатып, ниндидер көйне исенә төшерергә азаплана иде.* М.Маликова. *Бераздан ун телле тальянын күтәреп чыкты да, баскычка утырып, шыңгырдатып уйнап та җибәрде.* Н.Әхмәдиев

**Шыңгырдата башлау** Шыңгырдатырга тотыну. *Бу вакытта югары катта кемдер нигәдер кыңгырау шыңгырдата башлады.* Г.Ибраһимов. *Аннан тагын гармунын шыңгырдата башлый ул.* Ф.Җамалетдинова

**Шыңгырдата тору** Әлегә шыңгырдату. *Ашаган савытларны җыештырырга булышырга тотынган идем, Рәшит әфәнде: «Борчылма, мин өстәлдән алып кына куям, калганы – хатын эше, әнә гармун шыңгырдата тор ---», – дип, күрше бүлмәгә төртеп күрсәтте.* Ватаным Татарстан

**Шыңгырдата төшү** Тагы да ныграк, катырак шыңгырдату. *Ул кымызны биргәндә, кызлар тез йөгенеп, бармаклары тулы чылбырлы алтын-көмеш балдаклары белән касәләргә юри чиертеп, чыңгыраган авазлар чыгару дисеңме. Бизәкле читекләрене юри шыңгырдата төшү дисеңме. Бар да бар.* Р.Батулла

**Шыңгырдатып алу** Кыска гына вакыт шыңгырдату. *Идәндә торган баянны күргәч: – Кем уйный? Мөмкин булса, шыңгырдатып алыйм әле, – дип, кулына баянны алды ---.* Г.Галиева. *Җәмил гармунны бер-ике тапкыр шыңгырдатып алгач уйнап җибәрде.* З.Мәхмүди

**Шыңгырдатып карау** Тикшерү-белү максаты белән шыңгырдату. *Гармун сатып алып, кызыгып шыңгырдатып та караган идем.* Г.Галиев. *Җыйнак кына гәүдәле, кояшта янган карасу йөзле бер егет, кая алайса шыңгырдатып карыйк, дип, беркем дә кагылырга кыймаган өр-яңа гармунга үрелде.* Р.Кәрами

**Шыңгырдатып кую** Бер тапкыр яки рәттән берничә тапкыр шыңгырдату. *Менә бермәлне усал гына кыяфәтле бер адәм бер кечкенә генә сары нәрсәне алды да берничә мәртәбә шыңгырдатып куйды.* Г.Ибраһимов. *Касыйм агай гармунының бакасын шыңгырдатып куйды.* А.Әхмәтгалиева

**Шыңгырдатып тору** Өзлексез яки әледән-әле шыңгырдату; сөйләү моментында шыңгырдату. *Гармун күреген менә хәзер тартып җибәрер, бәясен күтәрер өчен, юри шыңгырдатып торадыр.* Ш.Галиев

**ШЫҢГЫРДАТЫП** *рәв.* 1) Тиз генә, җитез генә; шартлатып. *Аннары камераның тимер ишеген чалт-чолт китереп ачтылар да, аннан бер кешене җилкәсеннән төртеп кертеп, яңадан шыңгырдатып бикләп куйдылар.* Г.Әпсәләмов. *Кайткан да атасына, шыңгырдатып, гүрничәдәй йорт салып биргән, ди.* М.Маликова

2) Әйбәтләп, җиренә җиткереп, тиешле дәрәҗәдә. *Күрше колхоз ферма салды, Шыңгырдатып нараттан.* Г.Афзал. *Заман үзгәрде димәктән, авыл халкына әллә ни булды. Берсеннән-берсе үчеккәндәй, шыңгырдатып, алтышар почмаклы йортлар салалар.* Р.Фәизов

3) Каты итеп, тавышланып. *Ул туктап тамак кырды, хатын-кыз яулыгы кадәр кулъяулыгын чыгарып, шыңгырдатып, борынын сеңгерде ---.* Ф.Садриев

**ШЫҢГЫРДА́У** *ф.* 1) Нәрсә дә булса шыңгыр-шыңгыр килү, шундый тавыш чыгару. *Борһан абзыйның капкасы да, ниһаять, төбенә хәтле шыңгырдап ачылды.* Ә.Еники. *Километрга сузылган озын состав буферлары бер-берсенә бәрелә дә, баштан ахырга таба металл тавышлары шыңгырдап йөгерә.* Ә.Баян

2) Ямьсез, шыгырдаулы тавыш бирү. *Тәлинкәсе сылтый энәгә, Энә әйтә: – Сәбәп синдер! – ди; Әрләшәләр, шелтә әләгә... Ә патефон һаман шыңгырдый.* З.Нури. *--- гармуным соңгы вакытта элеккечә очынып-очынып җырламый, шыңгырдый да туктый, шыңгырдый да туктый.* Ф.Яруллин

3) Кайтаваз булып яңгырау, шаңгырдау. *Ул шыңгырдап торган зур урманнар, Биек-биек таулар, киң кырлар --- Барысы хәзер синең милкең болар.* Б.Рәхмәт. *Фәһимә, җырлый-җырлый, тәрәзә пыялаларын юа, өй шыңгырдап яңгырап тора ---.* Д.Каюмова

4) Яңгырап торган музыкаль матур тавыш белән җырлау, сөйләү, көлү һ.б. *Һаҗәр аның күзләренә текәлеп тыңлый, ләкин сүзләрен аңламый, тик егетнең көмештәй шыңгырдап аккан саф ачык тавышын ишетә иде.* Г.Ибраһимов. *Хәйдәров тагын шыңгырдап көлеп алды.* Т.Миңнуллин

5) *к.* **шыңшу** (*4 мәгъ.*). *Ул әлеге концертта Гүзәлия җырлаган «Мәхәббәт» җырын авыз эченнән шыңгырдап, иденнәрен җыештыра башлады.* Ф.Яруллин

6) Саңгырау шартлау, шарт иткән тавыш чыгару. *--- утын түмәркәсе, шыңгырдап, урталай ярыла да, сызгырып, ике якка оча.* Г.Бәширов

7) Тигез генә гөжләү. *Түр башындагы самавыр әле сүнеп өлгермәгән, шыңгырдый.* Сөембикә

8) *күч. к.* **шыгырдау** (*3 мәгъ.*). *Картиналарны үтереп мактадылар, моңарчы ватык арба сыман шыңгырдап йөргән автор турында «егет җигелеп эшләгән» диештеләр.* Н.Гыйматдинова. *Кәҗәсен савып бетергәч, Мөхлисә карчык, шыңгырдый-шыңгырдый, урыныннан кузгалды.* Г.Әдһәмова

9) *күч. хуплм.* Сөйләү, әйтү, сукалау. *Президиумда кыбырсып утырган әлеге кешеләрнең берсе инде менә бүтәнчәрәк шыңгырдый: – Ярар, ник чәнчелеп китми планёркасы!* Э.Касыймов

10) *күч. к.* **шыгырдау** (*4 мәгъ.*). *«Исәнлек-саулык ничек соң?» – дисәң: «Йөрибез шунда шыңгырдап!» – ди, картларга охшатып.* Ш.Галиев

11) *күч.* Берәр урын авырту, сызлау. *Хатыйп абзый яшьтәше Нурислам абзыйдан: «Нәрсә, Нурис, арыдыңмы, билләрең шыңгырдый башладымы?» – дип сорап куйды.* Р.Әхмәтов

◊ **Шыңгырдап торган** 1) Нык, коры, черемәгән, бәрсәң, тавыш бирә торган. *Йортлар шыңгырдап торган ылыс бүрәнәләрдән салынган.* М.Әмирханов. *Сараның туктаусыз ягып торсаң да өч еллык утыны бар өстенә, шул малай әнә тагын бер машина шыңгырдап торган каен утыны алып кайткан.* В.Нуруллин; 2) Коры, кипкән. *Җәйләрен ирләр күмер, дегет эшләгәннәр, --- тимерче алачыкларын шыңгырдап торган нарат күмере белән тәэмин иткәннәр.* М.Мәһдиев. *Шыңгырдап торган юл булса, --- авылларга чыгып йөреп кайтырга да авырсынмас иде ул.* Ф.Сәйфи-Казанлы; 3) *к.* **шыгырдап торган** (*1 мәгъ.*). *Мәннән абзый шул агач төбенә тезләнде дә шыңгырдап торган яңа пычкыны кирткә каршы якка куйды.* Г.Гобәй. *Сугышның соңгы елында әни --- шыңгырдап торган хром күн итекне, тагын нәрсәләрнедер ике пот арыш онына алыштырып кайтты.* Ә.Рәшит; 4) Гайрәтле, көчле, егәрле. *Машинистлар картлык ялына илле биштән чыгалар һәм аларның күбесе – әле егетләр шикелле шыңгырдап торган, тап-таза кешеләр.* Р.Фәизов

**Шыңгырдап алу** Бераз яки бер тапкыр шыңгырдау. *Авыл беразга тын тора – кичке аш вакыты. Ләкин бу тынлык озакка түгел. Бу – югары яки түбән очтан гармун теленең бер генә шыңгырдап алуына кадәр генә.* М.Мәһдиев

**Шыңгырдап калу** Берәр нәрсәдән соң шыңгырдау. *Скрипка кылына берәр чебен кунып очып киткәндә, скрипка шыңгырдап калган шикелле, Габдулла Тукайның сазына дөньяның сизелерсизелмәс җилләре кагылганда да, аның кыллары чыңламый калмый.* Н.Нәҗми

**Шыңгырдап карау** Сынау-тикшерү өчен шыңгырдау. --- *һәр җиргә Мәскәү күзәтчесе кую да бик дөрес. Ышанырга ярамый бүтәннәргә. Һәр районе судиясен Мәскәү раслау искиткеч дөрес. Судияң Мәскәүнеке булгач – шыңгырдап кара.* Т.Миңнуллин

**Шыңгырдап китү** Шыңгырдый башлау. *Аның көмеш тавышы бүлмә эчендә шыңгырдап китә.* А.Алиш. *Ятим малайның күңеле эскрипкә кылы кебек бит аның: әз генә кагылдыңмы, шундук шыңгырдап китәргә тора.* Г.Ахунов

**Шыңгырдап кую** Бер тапкыр шыңгырдау. *Минем уйларымны бүлдереп, тальян шыңгырдап куйды.* Л.Ибраһим-Вәлиди

**Шыңгырдап тору** Өзлексез яки әледән-әле шыңгырдау; әле, хәзер шыңгырдау. *Тик өйалды баскычына аяк баскач кына искәрәсең: --- бишмәт итәкләре шакыраеп каткан да як-якка тырпайган, берәр нәрсәгә бәрелүгә, калай шикелле шыңгырдап тора.* Г.Бәширов. *Нарат өйнең диварлары шатлык авазларыннан шыңгырдап тора!* Р.Хәбибуллина

**Шыңгырдый башлау** Шыңгырдарга тотыну. *Олан уянды да шыңгырдый башлады.* Э.Касыймов. *Кечкенәрәкләр минеке бәләкәй дип шыңгырдый башласалар, әти кулындагы агач кашык комсызланучының маңгаена төшәргә мөмкин.* Ф.Яруллин

**ШЫҢГЫ́Р-ШЫҢГЫР** *иярт.* Металл яки шундый каты әйберләр берберенә бәрелүдән бертуктаусыз яки әледән-әле бер ритмга чыгып торган калын, саңгырау калтыраулы тавышны белдерә. *Менә бервакыт түбән очтан кызларның, дәртле бер уенчак көйгә салып, шыңгыр-шыңгыр киндер тукмаклаган тавышлары ишетелә башлады.* Л.Гыйззәтуллина. *Сәбиләне тизрәк тулай торагына озатып куям да трамвай тукталышына йөгерәм. ...Дыңгырдыңгыр, шыңгыр-шыңгыр – трамвайның үз җыры.* Г.Гомәр

2) *к.* **шыгыр-шыгыр**. *Буйга җиткән ак күлмәкле кыз бала шыңгыр-шыңгыр, шыңгыр-шыңгыр су ала.* Р.Мингалимов

**ШЫҢГЫ́Р-ШЫҢГЫР ИТҮ** *ф.* Шыңгырдаган тавыш чыгару. *Атлар пошкыруы, тәгәрмәчләр шыгырдавы, чишеп ташларга онытылган кыңгырауларының шыңгыр-шыңгыр итеп баруы ишетелеп тора башлады.* И.Гази

**ШЫҢГЫ́Р-ШЫҢГЫР КИЛҮ** *ф. к.* **шыңгыр-шыңгыр итү**. *...Кышкы зәмһәрир салкын иде. --- Өй бүрәнәләре шыңгыр-шыңгыр килеп ярыла.* М.Әмирханов. *Гармун шыңгыр-шыңгыр килгәннән яшьләрнең кәефе бозыла.* Ф.Яхин. *Шыңгыр-шыңгыр килеп, автобус ишегә ябылды.* Сөембикә

**ШЫҢКАЙТУ** *ф.* Шомрайту, шомарту, сагайту, колак салу. *Ата, --- башын алга суза төшеп, ике кулы белән таягына басып: – Мин сине колакларымны шыңкайтып тыңладым, Зәбир.* Г.Ахунов

**ШЫҢКАЮ** *ф.* 1) Селкенмичә тик тору, хәрәкәтсез калу. *Тора солдат кыш буенча, гүр-окопта шыңкаеп, Мәрхәмәтсез кышкы салкынны татый хәлдән таеп.* Аң

2) *гади с.* Качу, шылу, таю, ычкыну. *Әхәт сикереп торды да, ---Сәлимгә таба килә башлады. Тегесе, артына борылып карый-карый, урман ягына шыңкаерга ашыкты.* Г.Бәширов

**Шыңкая башлау** Шыңкаерга тотыну. *Кайберләре исә, артларына карыйкарый, куаклар артына шыңкая башладылар.* Г.Бәширов

**ШЫҢКЫРА́У** *ф. к.* **шыгырдау** (*1 мәгъ.*). *Еректан ук майсыз арба тавышы белән шыңкырап, трамвай килеп җитте. Халык күп җыелган иде, көчкә генә түбәнге басмачага эләгә алдым.* Ш.Маннур

**ШЫҢРА́У** *ф. к.* **шыңгырау**. *Хуҗа кулындагы чүлмәк шыңрамый гына ватыла.* Мәкаль. *Еректагы нарат башларының Ярым тавыш белән шыңравы Хәтерләтә зарлы карт маньчжурның Моңсу гына сузып җырлавын.* Ш.Маннур

**ШЫҢШУ** *ф.* 1) Чинау, чинап елау, тонык кына чыелдау (эт һ.б. хайваннар тур.). *Җәкәү эшкә бармаган көннәрдә Актырнак ни эшләргә белмичә урамда чабып йөри, шыңшый, сыкрана.* Г.Рәхим. *Эт --- шыңшый, сызлана, яралы урыннарын ялый.* З.Мәхмүди

2) Елау (гадәттә, ачуны китереп юкка-барга елау тур.) // Еламсырау. *Ул арада Йосыф кахан янә чатырга әйләнеп керде, шыңшый башлаган баланы кулына алды; сабый, еларга җыенып, йөзен чытты.* М.Хәбибуллин. *Балаларның --- күбесе тавыш-тынсыз, хәрәкәтсез, кайсылары кыймылдый, шыңшый, сирәге кычкырып елый.* М.Маликова

3) *ирон.* Борын астыннан гына, әкрен генә җырлау, тавышны күтәрмичә генә җырлау. *Гөлчирә төпсез күз карашын гадәттән тыш сагыш белән кояш батышы ягына текәгән дә шыңшый иде: Тракторист – майлы крич, Хур иттең башларымны.* М.Мәһдиев. *Карт кына бер көтүче, сарыклар утлаганга карап, таягына таянган да тыныч ләззәт илә борын астыннан гына бер көй шыңшый иде.* Р.Батулла

4) *күч.* Ризасызлык, канәгатьсезлек белдереп зарлану, сукрану, сукранып сөйләнү. *Бу ач яңаклы адәм Фәритнең үз күңеленә дә нигәдер ятып бетми иде. Тотып яманларлык начар ягы да юк шикелле – әзрәк шыңшый, мескенләнә – анысы бар.* Г.Әпсәләмов. *Тик ни гаҗәп, соңгы вакытта һәрвакыт зарланып, мескенләнеп, кызгандырып көн күрүче, соранып, шыңшып яшәүче ир-егетләр күбәйде.* Р.Миңнуллин

**Шыңшый башлау** Шыңшырга тотыну. *Ул кычкырган тавышка уянган малайлар көйсезләнә, шыңшый башладылар.* А.Гыйләҗев. *Иртән бер җырны шыңшый башласа, шуны көне буе суза.* М.Мәһдиев

**Шыңшып алу** Берара, бераз гына шыңшу. *Булат, озак елап өзлеккән бала, кебек яңадан шыңшып алды.* М.Әхмәтшина. *Дамка бер адым алга атлый да Галиягә таба борылып карый, әкрен генә шыңшып ала.* Г.Әхмәтова

**Шыңшып җибәрү** Уйламаганда, кинәт шыңшый башлау. *Бер карчык: «Мәчетебез җылый-й!» – дип, сузып кына шыңшып та җибәрде.* Ә.Еники

**Шыңшып йөрү** Һәрдаим, әледән-әле шыңшу. *Беренче көннәрдә кызлар: «Кая килеп эләктек без?» – дип шактый шыңшып йөрсәләр дә, тора-бара ияләштеләр тагын.* А.Әхмәтгалиева. *Театр училищесында укыганда, Камал театрында беренче мәртәбә «Янар чәчәк» спектаклен карагач, озак вакытлар шул әсәрдәге җырны эчтән шыңшып йөрдем.* Х.Мәхмүтов

**Шыңшып карау** Шыңшырга омтылу, тырышу; сынау өчен шыңшу. *Нинди авыр юлда, көзге Идел өстендә калтыраса да, елау түгел, шыңшып та карамады сабый.* Ә.Баян. *Күзләрем йомыла башлагач, күңелгә килгән бер көйне сызгырырга тотындым. Җыр да шыңшып карадым.* А.Гыйләҗев

**Шыңшып кую** Көтмәгәндә, кинәт шыңшу; бер тапкыр шыңшу. *Исән эт --- тып-тын гына алар артыннан иярде. Ул әллә нигә өзек-өзек итеп шыңшып куя ---.* А.Вергазов. *Женя моңа кадәр ярым шаярып, ярым чыны белән туристлар арасында бик популяр җырның «Мама, я хочу домой» дигән кисәген җырлап я шыңшып куя иде.* А.Хәсәнов

**Шыңшып тору** Хәзерге вакытта шыңшу; һәрдаим яки әледән-әле шыңшу. *Туктар, хуҗасы тукмаклап аткан эт сыман, беравык еламсырап, шыңшып торды.* Х.Ибраһим. *Балконлы йортлар артыннан – каяндыр безнең халәтләргә иш булып, тальян гармун шыңшып торды.* Р.Фәйзуллин

**Шыңшып яту** *сөйл. к.* **шыңшып тору**. *Мин әле күтәреләчәкмен, мин егылып, шыңшып ята торган мескен егетләрдән түгел.* Н.Гыйматдинова. *Алар бөтенесе бергә җыелып, Шәрифҗанның якасыннан алдылар да аны ятагына әйләндереп салдылар. Менә ул ничә көн инде шунда шыңшып ята.* Р.Гыйззәтуллин

**ШЫП-** *кис.* [ш] авазына башланган кайбер сыйфат һәм рәвешләргә ялганып, артыклык дәрәҗәсе ясый торган алкисәкчә. *Боларны күргәч, бик күп кешеләр шып-шым булдылар.* М.Гафури. *Күрше авыллардагы байларның амбарлары барысыныкы да шып-шыр.* В.Нуруллин

**ШЫП** I *иярт. к.* **шап**. *Артыгын әйтеп ташладым дигәндер, шәфкать туташы шып туктап калды.* Н.Әхмәдиев. *Ни гаҗәп, хуҗасы килеп шулай башыннан сыпыргач, бармак та янап алгач, Чатан әле генә ду килеп котырынган җиреннән шып тынып кала.* А.Хәсәнов. *Капка шып итеп ябылды.* Х.Ибраһим

◊ **Шып итеп кереп утыру** 1) Нинди дә булса әйбергә төгәл туры килү; таман булу; 2) Төгәл кереп урнашу, утыру. *Сәрби авызыннан алар әллә ничек ягымлы тезелеп чыгалар да, бер җиргә түгелми-чәчелми, шып итеп йөрәккә кереп утыралар.* Ә.Фәйзи

**ШЫП** II *и.* Вак агач кадак. *«Тырышкан гына ташка кадак кагар», ---кадак дигәне нәрсә ул тагы, шыпмы?* Г.Әпсәләмов

**ШЫПАН** *рәв. сир.* Сиздерми, мыштым гына, тавыш-тын чыгармыйча. *--- түрәләр үзләре каршында койрыгын кысып, шыпан гына утырып, гаепле кеше сыман курка-курка әкрен генә сөйләгәнне хуп күрәләр.* Т.Миңнуллин. *Тәти сукбай шыпан чигенә, Батыр сукбай кушуч сүгенә ---.* Р.Идиятуллин

**ШЫПА́Н-ШЫПАН** *рәв.* 1) Бер-бер артлы сиздермичә, мыштым гына, шыпырт кына. *Син югында шыпан-шыпан гына Таңсылу янына ир-ат кергәли иде.* А.Гыйләҗев. *Миңнулла җиңде: бунтчылар шыпан-шыпан гына башта өйдән, аннары --- ишегалдыннан ук чыгып киттеләр.* В.Нуруллин

2) Сиздермичә, яшертен, астан гына. *Әби-чәбиләргә шыпан-шыпан гына капчык-капчык икмәк сатып ятуын да сизә башладылар.* В.Нуриев

**ШЫПАЮ** *ф. сөйл.* Шып тыну, тынып калу, шым булу; тавыш-тын чыгармау. *Хафиз --- як-ягына карангалап, шыпаеп кына келәт янына килеп тыңлый да келәт тәрәзәсен чиертә.* Г.Камал

**ШЫПЛАНУ** *ф. төш. юн. к.* **шыплау**. *Кырыйлары алтынсыман яфраклы чикләвек агачлары белән шыпланган кечкенә аулак урман юлында без һаман дүртәү генә.* А.Гыйләҗев. *Каршыда түбәләре тышланган алачыклар рәте, аларның һәрберсе кием-салым белән шыпланган иде.* Н.Гыйматдинова. *Әюпов кабалана башлады. Чыга торган ишек янында шыпланган халык ташкынына кушылды.* Ә.Мушинский

**ШЫПЛАП** *рәв.* Туп-тулы, тыптыгыз итеп, тыгызлап; күпләп. *Төрмәчеләр белән шыплап тулган эшелон Колымадан кузгалган да, --- ниһаять, шушы төбәккә килеп төшкән.* М.Галиев. *Бу сүзләрдән Гайфулла кызарып куйды һәм, тамак кыргалап: – Балдыз булмаса, моның кадәр курмы әзерләп булмасые. Сәндерә, утлык шыплап тулды.* Ф.Яруллин

**ШЫПЛА́У** *ф.* 1) Буш урын калдырмыйча, тып-тыгыз итеп, тыгызлап урнаштыру; бик тыгыз урнашу

2) Мөлдерәмә тулы итеп салу; күп тутыру. *Кәмәләрнең кайберләренә агач, таш, кайберләренә шыплап өеп ашлык, кайберсенә чүлмәктер, савыт-сабадыр төялгән иде.* Н.Фәттах. *--- әйлә җитеп килгәндә, --- капчыкларда шыплап тутырылган бодай җыйналды, барлыгы җитмеш алты капчык бодай иде.* З.Зәйнуллин. *Кыш буе химия белән «шыплаган» алмаларны сатып алырга мәҗбүрбез.* Ватаным Татарстан

**ШЫПТАЛЫ** *и. фар. диал. к.* **шәфталу**. *Монда алабутаны түгел, арыш ипиен дә белмиләр. Ашаганыбыз – апак калач та дөге боткасы. Өрек, йөзем, шыпталы.* Ә.Еники

**ШЫПТЫРДАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **шыптырдау**

2) Шыптырдаган тавыш чыгару. *Аның янынан узган саен, шул тезелеп торган ак көймәләрнең берсенә утырып, ишкәкләр белән суга шыптырдата-шыптырдата, әллә кайларга ишеп китәсе килә.* Гали Рәхим

**ШЫПТЫРДА́У** *ф.* Шыптыр-шыптыр килү, шундый тавыш чыгару. *Аяк астында коры яфраклар шыптырдады*

**Шыптырдап кую** Аз гына, бер тапкыр шыптырдау

**Шыптырдап тору** Әле, хәзерге вакытта, сөйләгән моментта яисә һәрвакыт шыптырдау

**ШЫПТЫ́Р-ШЫПТЫР** *иярт.* 1) Яфрак, кәгазь һ.б.ш. әйберләр берберсенә кагылганда барлыкка килгән өзек-өзек җиңелчә тавышны белдерә

2) *к.* **шаптыр-шоптыр**. *Шыптыр-шыптыр су ерып бару*

**ШЫ́П-ШЫП** *иярт.* **1.** 1) Эре тамчылар бер-бер артлы тамганда, нәрсә дә булса каты җирлеккә бер-бер артлы төшкәндә, каты өслеккә нык басып йөргәндә, сикергәләгәндә чыккан тавышны белдерә; тып-тып. *Күпмедер вакыттан соң тишек түбәдән шып-шып тамчы тамганын тоеп, ул тагын күзләрен ачып җибәрде.* Н.Фәттах. *Кышның эт эчәге үләне кебек озын төннәрендә җиделе лампа астында шып-шып киндер сугып, күз нурларын әз түкмәде Мәгъдәния.* Ф.Яруллин

2) *к.* **шаптыр-шоптыр**. *Бервакыт су өстендә нәрсәдер шып-шып килә башлаган, ди.* Г.Гали

**2.** *рәв. мәгъ.* Шундый тавыш чыгарып. *Башкалар да, тарлавык авызына килеп басканчы ук, тезгән домино ауган кебек, шып-шып ава башладылар.* А.Хәсәнов. *Шып-шып атлап, бер егет бакчага килеп керде, як-ягына каранды да гөлләрнең куерак булган җиренә килеп утырды.* Мирас

**ШЫП-ШЫ́П ИТҮ** *ф.* Шып-шып кебек тавыш чыгару. *Андагы алып баручыларның киемнәреннән шып-шып итеп су тамып тора.* Р.Әхмирова

**ШЫП-ШЫ́П КИЛҮ** *ф. к.* **шып-шы́п итү**

**ШЫПЫЛДАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **шыпылдау**

2) Селкеткәләү, калтыратып бәргәләү, каккалау. *Көтүдәге холыксыз кәҗә тәкәсе инде киерелеп торып маташа, моңа бөтен кәҗә игътибар бирә, колакларын шыпылдатып, башларын каты селкеп, йокыдан айныйлар, ләкин сыер халкының торырга исәбе юк әле.* М.Мәһдиев

3) *гади с. к.* Үтерү, шапылдату (*5 мәгъ.*). *– Измайловны качырасың да, шул көнне үк теге чүпрәкбашны шыпылдатасың. Ә? Очы очка ялгана бит! – Серадов --- ишекле-түрле йөри башлады. – Хатынны кем үтергән, кемгә кирәк бу, диячәкләр.* З.Фәтхетдинов

**Шыпылдата башлау** Шыпылдарга тотыну

**Шыпылдатып алу** Бераз яки бер тапкыр шыпылдату. *– Тагын бер кат сәламлим сезне! – Ул, кулын чигәсенә тиереп, үкчәләрен шыпылдатып алды.* Г.Гомәр

**ШЫПЫЛДАТЫП** *рәв.* Озын-озак уйлап тормастан, тиз генә. *Эшебез әзер инде. Әзер дигәнем шул – үз диплом эшемнең караламасы сакланган иде, мин шуны, ике кич утырып, бераз үзгәрткәләдем дә, шыпылдатып күчердем да бирдем.* К.Тимбикова

**ШЫПЫЛДА́У** *ф.* 1) Шып-шып итеп таму, шабырдау. *Менә өй түбәләренә, коймаларга, шыпылдап, берничә бөртек эре яңгыр төште.* Г.Бәширов

2) Бер әйбер икенчесенә киң йөзе белән бәрелгәндә, каты җирлеккә төшкәндә чыккан саңгырау, тонык тавышны белдерә. *Ислам кискен хәрәкәт белән кармак сабын югары күтәрде һәм --- яр читенә бармак озынлыгы җимбалык шыпылдап килеп төште.* Р.Солнцев

3) Кисәк, көтелмәгәндә, тиз егылу, төшү, утыру. *Аякларына баса башлаган Вил, тез астына суктылармыни, шыпылдап урынына утырды.* З.Зәйнуллин

4) Аермачык булып яңгырау, нык яңгырау. *Җәйге караңгы кичләрдә яркanat, дәһшәтле шыпылдап, синең колак төбеннән генә очып уза, тәннәрең эсселе-суыклы булып кала.* М.Мәһдиев

5) *к.* **шапырдау**. *Тавыш та юк, атыш та юк. Шыпылдый ишкәкләр генә.* Г.Латыйп

6) *к.* **шыплау**. *Ә менә шыпылдап тулган автобусларда этешә-төртешә басып торулар – картларга ныклыкларын тикшереп карарга шәп урын.* Ф.Дәүләтбаев

**Шыпылдап алу** Бераз яки бер тапкыр шыпылдау. *Эре яңгыр тамчылары шыпылдап алды*

**Шыпылдап кую** Бер тапкыр шыпылдау

**Шыпылдап тору** Әле, хәзерге, сөйләгән моментта яисә даими шыпылдау

**ШЫПЫРДАТУ** *ф. к. йөкл. юн.* **шыпырдау**

**ШЫПЫРДА́У** *ф.* 1) *к.* **шапырдау**. *Шыпырдап чыкты күлдән бер матур хур, Кап-кара толымнарын болгыйболгый.* Г.Тукай. *[Фирдәвеснең] кыска балтырлы бутыена шыпырдап су тулды.* Т.Миңнуллин

2) Шабырдау, шыбырдау. *Өстенә, эре яңгыр кебек шыпырдап, пуля ява башлады.* Г.Бәширов

3) Ачып чемердәп тору, күбекләнү, күбекләр чыгару. *Тагы ике углан куй тиресеннән ясаган баш күнәк белән шыпырдап кайнап торган кымыз китерделәр.* Г.Гобәйдуллин

4) *гади с. к.* **шыбырдау** (*2 мәгъ.*). *– Шыпырдама, сеңел! Бир, Сабан туена хәтле тагын әчеп өлгерә ул [бал].* Г.Гобәй. *Әз генә кеше шыпырдый, кирегә сукалап йөри башласа, Абага районында бу кешене юк итәләр...* Н.Хәсәнов

**Шыпырдап алу** Бераз яки бер тапкыр шыпырдау. *Су өстендә ишкәкләр шыпырдап алды*

**ШЫПЫРДАШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **шыпырдау**. *Каз белән үрдәкләр --- су астына борыннарын тыгалар да шыпырдашалар гына.* А.Алиш. *Аның кычкыруыннан сискәнеп, бакчадагы агач яфраклары шыпырдаштылар.* Г.Рәхим

2) Басынкы гына ыгы-зыгы килү, тынычсызлану. *Өйгә җыйналган кешеләр төркеме арасында шыпырдашу, акрынлап сөйләшүләр ишетелде.* Ш.Камал

3) Тыпырдашу. *Ул көндезен дә, кичен дә гел караңгы килеш тора, җилдавылда гүли, безнең уйлавыбызча, анда ниндидер куркыныч җеннәр, йорт ияләре йөри, аксак тәпиләре белән бертуктаусыз шыпырдашалар...* Безнең мирас

**Шыпырдаша башлау** Шыпырдарга тотыну. *Укучылар ризасызлыкларын белдереп шыпырдаша башлады*

**Шыпырдашып алу** Бераз яки бер тапкыр шыпырдашу. *Килгән кунаклар шыпырдашып алды*

**ШЫПЫРТ** *рәв.* **1.** 1) Акрын гына, ишетелер-ишетелмәс, пышылдап. *Ләкин Салих миңа орынмады, бары сул кулымны каты гына кысты да колагыма шыпырт кына: «Хуш, Гөлгенәм!» – диде.* Ф.Әмирхан. *Күбесе үзара таныш булса кирәк, шыпырт кына хәл-әхвәл белешәләр, туган-тумачаларын сорашалар.* М.Маликова

2) Бернинди дә тавыш чыгармыйча, тып-тын, тавыш-тынсыз гына. *Кулларын балчык астыннан җиңел алды, әмма аякларын «коткарырга» күп көч түкте, сантиметрлап үзенә таба тартты да тартты. Ул моны бик шыпырт эшләде.* Х.Камалов

3) Гаугасыз, бәхәссез рәвештә. *Кайгысы була икән, ул аны болай шыпырт кына да уздырып җибәрә ала.* Г.Әпсәләмов

4) Яшерен рәвештә, яшертен генә, сиздермичә, сиздермәскә тырышып. *Районнагы таныш-белешләренә берничә түшкә сарык озатып карады, аннан шыпырт кына районга ике йөк каен утыны илтеп кайтты.* М.Мәһдиев. *Авызга капканчы, әбием күрмиме, сизмиме икән дип шикләнеп, аның --- күзләренә карыйм. Бераз гына карап торам да, сизмәс әле, дип, шыпырт кына тәмле җимешне авызыма кабам.* Н.Каштанов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Тыныч холыклы, тыйнак һәм гаугасыз. *Янәшәдә балалар йорты. Мондагылар бөтенләй үзгә: шыпырт, боеклар. Артык тын, тәртипле.* Ш.Галиев. *Зиннур – китәсе егет – шыпырт, юаш адәм икән, өстәл почмагында тик утырды.* М.Мәһдиев

2) Кешегә белдерелми торган, яшерен, серле. *Безнең апайның аулак өйләрдә, кичке уеннарда шул усал егет белән бергәрәк булуы, бер-берсенә ниндидер шыпырт сүзләр әйтүләре минем дә күзгә чалынганы бар.* Г.Бәширов. *– Белмим инде, килендәш, --- нишләргә дә аптыраган, – дип сөйләнгәләп, пышык-пышык елап байтак утыргач, шыпырт йомышым бар иде сиңа, дип, әнине өйалдына алып чыгып китте.* В.Нуруллин

3) Әкрен, тыенкы, басынкы. *– Зәмзәм суымы? – диде ул шыпырт тавыш белән.* М.Мәһдиев. *Озын, сөякчел башын бары тик Заһир абыйның иңенә аның шыпырт тавыш белән назлап дәшкәнен ишетер өчен генә ия иде ул.* М.Маликова

**3.** *ы. мәгъ.* Сөйләшмәскә, тик торырга өндәгән сүз; чү, тс. *– Шыпырт, – диде Владимир, бармагын иреннәренә тидереп.* Р.Кәрами. *– Кем ул? Исеме, фамилиясе? – Тс-с, шыпырт...* Н.Гыйматдинова. *Шыпырт, чыгалар бугай!* Р.Сәгъди

**ШЫПЫРТЛАНУ** *ф.* 1) Тыну, тынып калу, тын калу. *Төнлә, ай яктырып торган чакта, болытлар таза ак булалар: булган нәрсәдә тынычланып шыпыртланганда алар йоклаган ак бәрәннәр көтүе кебек булып торалар.* М.Радлов

2) Әкренәю, кимү, чак кына ишетелерлек хәлгә килү. *– Су кушу закон белән тыела, Алла бәндәсе! Ими төбен савып бетермисеңме әллә, диюем. –Мөдирнең тавышы шыпыртланды.* Х.Камалов

3) Бәхәс, дау, хәрәкәт, шау-шу, ыгы-зыгы һ.б. экренәю, кискенлеге яки зыяны бетү, басылу, тынычлану. *[Мияссәр:] Бүген карыйм, карт-корылар гаҗәп иртә уянганнар да коридорда кыштыр-мыштыр йөриләр. Сөйләшүләр шыпыртланган.* А.Гыйләҗев

**ШЫПЫРТЛАП** *рәв. к.* **шыпырт**. *Роза бик шыпыртлап кына, тавыш чыгармаска тырышып кына өй эшләре белән булаша башлады.* Г.Рәхим. *Офицер, аны йокыдан уятудан курыккан төсле, --- янындагыларга шыпыртлабрак әмер бирде ---.* З.Фәтхетдинов

**ШЫПЫРТЛЫК** *и.* 1) Бернинди дә тавыш, шау-шу булмау хәле; тынлык

2) Сер саклау, белгертмәскә тырышу; астыртынлык. *Хәбәрне ул сер итеп кайбер кордашларына гына әйтте, вокзалда төркем булмаска тиеш, диде. Ул чактагы саклык, шыпыртлык, кайтучыны кыен хәлгә калдырмаска теләүдән дә.* Ш.Галиев

3) Тыныч, сабыр холык. *Без этидән тынычлыкка, шыпыртлыкка өйрәндек: безнең өйдә этиегез ял итә, тавышланмагыз, дигән кисәтү яшәде.* Безнең гәҗит

**ШЫПЫРТЫН** *рәв. к.* **шыпырт**. *Безнең большевик иптәш шыпыртын гына, мин сиңа әйтим, баргалап тора шул.* Ш.Камал. *Шулчагында китап кабул итү бүлмәсеннән спортчы кыяфәтендәге берәү чыкты. Әле генә Валентина Андреевна белән шыпыртын, юмакайланып сөйләшкән кеше.* А.Тимергалин

**ШЫПЫ́Р-ШЫПЫР** *иярт.* 1) Әкрен генә сөйләшкәндә чыккан тавышны белдерә; пыш-пыш, чыш-пыш. *Шуннан үзе дә яшен суккан шайтан кебек китте дә, тагы бер каһәренә барып, шыпыр-шыпыр сөйләргә тотынды...* Г.Исхакый

2) Аш яки сыек ашамлыкны зур йотымнар белән, ашыгып, суырып эчкәндә чыккан тавышны белдерә. *Малай шыпыр-шыпыр чәй эчте дә урамга йөгерде*

3) *к.* **шыбыр-шыбыр**. *Шыпыр да гына шыпыр яңгыр ява.* Җыр

**ШЫР** I *и. монг. иск.* Ике пот чамасы чәй тутырылган зур әрҗә; *русчасы:* **цибик**. *[Сәмигулла:] Шуның өчен бу юлы сездән чәйне бераз артыграк алырга дип килгән идем. --- Бу юлы инде, шаять, унике шыр итеп бирерсез дип өмид итәм.* Г.Камал. *Чәй шырын сүткәндә, аның эченнән сары кытай кәгазенең чыгуы --- кытайның сары булырга тиешлеге фикерен уятадыр иде.* Г.Газиз

**ШЫР** II *с.* **1.** 1) Буш, бернәрсәсез; шәрә. *Шыр кырда утырган бәләкәй генә ялгыз өй үзе, искереп-тузып, яртылаш җиргә кереп беткән.* Ә.Еники. *Безне --- бер машинага төяп, байтак кына ара алып бардылар да шыр дала уртасында төшерделәр.* А.Хәсәнов

2) Кеше арасында үзен тота белми торган, тәрбиясез, тыйнаксыз; әдәпсез, әдәп нормаларын санламаган. *– Ә нәрсә өчен яратырга соң сине, җаным? – Ни әйтсәң дә, бердәнберең бит, бердәнбер балаң. – Бер булдың да, шыр булдың шул инде!* Х.Ибраһим

3) Кирәгеннән тыш, артык. *Беренчесе бәрәңге боткасын шыр тоз итеп пешерә иде ---.* Н.Гыйматдинова

**2.** *кис. функ.* Сыйфатның артыклык дәрәҗәсен белдереп килә: бөтенләй, тулысынча. *Төпле кеше икән бу, дип сөенеп утырды Мостафин. Ә бит бер шыр мактанчык кеше булса да, берни эшли алмас идең.* Х.Камалов. *Аның кич саен зары бер иде: – Нигъмәт кандидатлык диссертациясен яклады. Шыр надан үзе!* Н.Гыйматдинова. *Дөрес, әзрәк тиле атын мактар, урта тиле үзен мактар, ә шыр тиле хатынын мактар, дигән әйтем дә бар.* З.Мәхмүди

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Бөтен киңлегенә, төбенә кадәр. *Иң әүвәл, җил-җил килеп, ишекләре шыр ачып куелган өйгә кереп чыкты.* М.Хәсәнов // Тулысынча, бөтенләй, бөтенләе белән. *Әнә Торна авылында бер кыз да акылдан шашкан булган. Көпә-көндез урамда шыр ялангач йөргән.* Т.Миңнуллин. *Иң хикмәтле сүзләр җүләр авызыннан чыга бит, абзый. Чөнки сүзгә киртә куючы тормоз юк, күңел капкасы шыр ачык.* Р.Габделхакова

2) Һәрвакыт, һәрчак, һаман, гел. *Шулай да без ул күмәчләрне ашадык. Ни генә димә, шыр бәрәңгедә генә утыру түгел инде, дип фикер йөрттек.* Г.Галиев

3) *диал.* Тыйнаксыз, тәртипсез, әдәпсез рәвештә; әхлак-әдәп кагыйдәләрен бозып. *Шыр кылану. Үзен шыр тоту*

◊ **Шыр акыру** *к.* **шар яру**. *--- карчыгын уятам дип тә тормады, шыр акырып команда бирде малайларга: – Янгансыз ич, чутрый-кутрыйлар. Живо өсләрегездән салыгыз, шлангтан су коендырам, штобы солдатларча таза-ныж булып үсегез.* Ф.Хөсни. *Тимерханның исемен ишетүгә... ир хатыны янына чүгәләде: – Нигә шыр акырасың?.. Персидәтелнең исемен әйтмәй генә аңлатып бир, дөньяны сасытасың бит...* Ф.Сафин. *Миңа кунак табыны тәтемәс инде, бала карау булыр. Әнә киракмәгәндә борынын сызгырта-сызгырта йоклый да аннарысы шыр акыра башлар әле, хикмәте Хода!* Г.Сабитов. **Шыр кычкыру** *к.* **шыр акыру**. *Бичара Шахтин акылын җуяр дәрәҗәдә каушый, курка, шыр кычкыра.* А.Хәсәнов. **Шыр сөяккә калу** Бик нык ябыгу, сөякләре тырпаеп тору. *Аяккуллары, йөзләре ачлыктан шешенгән яки шыр сөяккә калган, яшәү өметләре сүнгән кешеләр киләчәктән инде бер-*

*нәрсә дә көтмиләр.* Г.Әпсәләмов. *Күрмисеңмени, киптем-корыдым, шыр сөяккә калдым.* Р.Батулла. **Шыр чыккан** Артык, үтә, бик. *Шулкадәр нык шыгырдады кар, әйтерсең ки Ильясның беркатлы җүләр булуыннан кычкырып-кычкырып көлә һәм тәкрарлый: – Шыгырт, шыгырт, шыр чыккан, шыр чыккан җүләр.* Ә.Баян. *Әгәр әдәби әсәр язарга алынган берәү кеше күңеленең тибрәнешләренә диагноз куеп җавап бирергә тырыша икән, ул иҗатчы түгел. Я ул фән кешесе яки шыр чыккан надан.* Р.Низами. **Шыр ялангач** 1) Берни белән дә капланмаган, шәрә. *Хәзер монда шыр ялангач бодай басуы.* Л.Ихсанова. *Эшкә алуларына кәефе шат булса да, шул шыр ялангач, иләмсез агачларны күргәч, --- әллә кире борылыргамы, дип тә икеләнеп куйды.* Р.Габделхакова; 2) Бернәрсә дә булмаган, буш. *Бишме-алтымы тәрәзәсе урамга караган, шар тәгәрәтерлек шыр ялангач бер зур зал иде бу.* Ә.Еники. *Көзге, бер куйгач, эленеп тора инде шунда, стена шыр ялангач булмасын өчен.* Г.Рәхим. *Дала кебек шыр ялангач йорт калды аның карамагында.* З.Мәхмүди; 3) Бернәрсәсез, ярлы, хәерче. – *Соң, шулай булгач, алай бик тә «бөек» булгач, ни өчен үзе дә шыр ялангач һәм хәерче калды соң әле ул?* З.Зәйнуллин. *Малга карый җан кадерлерәк, дисәләр дә, малы юкның җаны да юк шул. Шыр ялангач калып булмый, гомер булса, яшиселәр бар.* Р.Габделхакова; 4) Нигезсез, дәлилсез. *Ләкин Дәүләтьяров – политик кеше, ул хәтле шыр ялангач итеп сөйләүне яратмый иде.* И.Гази. **Шыр яру** *к.* **шар яру**. *Рәхмәтләр укыйсы урынга кыз: «Җибәрегез аны, кабахәтләр, кыйнамагыз, ул – минем егетем», – дип шыр яра башлады.* Т.Галиуллин. *Ата белән улы бер-берсен якаларга тотындылар. --- Саҗидә апа, шыр ярып кычкыра-кычкыра, алар тирәсендә бөтерелде.* З.Хәким

**ШЫР** III *и.* Курку, шүрләү халәте

◊ **Шыр җибәрү** Бик нык курку, куркудан коелып төшү, өркеп калу. *Күз күреме кадәр җирдә боз өстенә ургылып су чыга башлый. Мондый хәлдә кем дә шыр җибәрер.* А.Хәсәнов. *Юк инде, агайне, Азнакай Хаҗи белән Урманай Шәвәлидән башкалары бүрене тоту түгел, күрүгә шыр җибәрәләр.* Н.Әхмәдиев

**ШЫРАГАЙ** *и. диал.* 1) Үтә беркатлы, эчкерсез, киң күңелле кеше. *Әнисә котыртты, мин шырагай тиз риза булдым.* Яңарыш

2) Бик нык юмарт, үзендә булганны уртаклашу ягын гына карый торган кеше

**ШЫРАГАЙЛАНУ** *ф. диал.* Үзен шырагайларча тоту. *Шырагайланып, карт алдына йөз тәңкә чыгарып салу да көлке бер ахмаклык кына булып тоела хәзер.* Ш.Маннур

**ШЫРАНТАЙ** *с. диал.* 1) Яфрак-ботаклары коелып шәрәләнгән, корыган, кипкән. – *Ә корыган агачны давыл кыеп сындырырга я төбе-тамыры белән куптарып ташларга да күп сорап тормый, – диде бабай. – Аннары череп юк була инде башта төз утырган, соңрак шырантайга әйләнгән агачың.* М.Хуҗин

2) *күч.* Артык ябык һәм озын буйлы. *[Ире] ябык кына озын ир. Шырантай.* Ә.Баян. *Иң кызыгы да шул: төркем эчендә мөдир белән Зәйниләргә килгән шырантай инженер да күзен челәйтеп басып тора.* Р.-Н.Гүнтәкин

**ШЫРАЮ** *ф. сөйл.* 1) Шәрәләнеп тырпаю, шырантай (*1 мәгъ.*) хәленә килү. *Такта умарталарны бер читкә өеп куйганнар, ятим калган казыклар, дүртәр-дүртәр тезелгән бичара солдатлар булып, шыраеп утыралар.* А.Гыйләҗев. *Мылтыклар бичараларга төбәлде, сигезенче багана гына буш, ул – ниндидер өн кебек, янаучы бармак сыман караеп, шыраеп утыра.* И.Салахов

2) *күч.* Авырудан, төрле рухи кичерешләрдән, авыр эштән һ.б.ш. ябыгу, кору, кибү. *Такы-токы ашап, ел тәүлегендә юньле ял күрмәгән «доходягалар» тагын да шыраеп калды, кабыргаларын әллә каян санарга була!* А.Гыйләҗев

**Шыраеп бетү** Бөтенләй, барысы да шыраю; шырайган хәлгә килү

**Шыраеп калу** Нәрсәдән дә булса шырайган хәлгә килеп, шуны саклау. *Чия агачларын рәттән төпләделәр. Бакча урынына күз көеге генә шыраеп калды.* Я.Зәнкиев

**Шыраеп тору** Озак вакыт яки хәзер шырайган хәлдә булу. *Ярты сәгатьтән Маһирә иңбашына зур агач тартма күтәргән берәүне ияртеп кайтты һәм, кулын сузып, икенче катта шыраеп торган буш өлгене күрсәтте.* А.Гыйләҗев. *Октябрь азаклары. Юеш кар юл буендагы әрем куакларына кунып, аларның башларын иде, анда-санда шыраеп торган кара куакларны агартты.* Т.Миңнуллин

**ШЫРДЫ́Й-БЫРДЫЙ** *с. сөйл.* Вактөяк; юклы-барлы, түбән сыйфатлы. *Хатын-кыз, өчаяк бастырып, таган аса, ир-ат утын җыя, алабуга, шыртлака кебек шырдый-бырдый балык тота ---.* А.Гыйләҗев

**ШЫ́Р ИТҮ** *ф.* Курку, шүрләү. *Чыпчык пыр иткәндә, йөрәге шыр итә.* Мәкаль

**ШЫРКЫЛДА́У** *ф.* 1) Җиңелчә генә шаулап көлү. – *Илһам Шакиров? Кайсы рота солдаты соң ул? – дип кабатлап, безне көлдерергә тотынды. Яшел печән паласыбызга тәгәрәшеп, озак шыркылдадык.* Ш.Маннапов. *Аның исеме чыкса, башкалар, кызык көтеп, шыркылдарга әзерләнеп утыра башлыйлар.* Л.Гыймадиева

2) *к.* **шыкырдау** (*3 мәгъ.*). *Баш очында карга каркылдады, якында гына саескан шыркылдады, артында козгын кычкырды.* Т.Гарипова

**Шыркылдап алу** Аз гына шыркылдау. *Ханнар зиратында уткойрыклар очынып йөри, чыркылдыйлар, ул да түгел, каяндыр килеп чыккан саескан шыркылдап ала.* М.Хәбибуллин. *Күгәрчен булып гөрли. Шунда ук кытыкланган кебек шыркылдап ала үзе. Ничек яратмаска мөмкин шундый хатынны!* З.Фәтхетдинов

**Шыркылдап җибәрү** Кинәт шыркылдый башлау

**Шыркылдап кую** Сирәк-сирәк яки бер тапкыр шыркылдау. *Ишегалдында тыелып кына, авыз эченнән генә бия шыркылдап куйды.* Г.Бәширов. *Риф елмаеп җибәрде, хәтта тамак төбе белән генә шыркылдап та куйды.* Көмеш кыңгырау

**Шыркылдап тору** Сөйләү моментында шыркылдау; һәрвакыт, еш, бертуктаусыз шыркылдау

**Шыркылдый башлау** Шыркылдарга тотыну. *Менә карт тирәккә саескан кунды һәм кызның яралы җанына өшеткеч аваз өстәп шыркылдый башлады.* Р.Сибат. *Җангир тагын баягы шикелле шыркылдый башлады.* Ә.Дусайлы

**ШЫРКЫЛДАШУ** *ф. урт. юн. к.* **шыркылдау**. *Без барыбыз да аның авызына гына карап утырабыз. Берәр сүз әйттеме, аны-моны карамыйча, шыркылдашырга гына торабыз.* Н.Фәттах. *Кемнәр анда, Күлләр буенда? Шыркылдашып кемнәр көләләр?* Н.Баян

**Шыркылдашып кую** Бер тапкыр шыркылдашу. --- *ул тагы көлеп җибәрде,*

*аңа кушылып, кунак белән Шәргыя дә шыркылдашып куйдылар.* Р.Солнцев

**ШЫРКЫЛДЫК** *с.* **1.** Күп шыркылдарга яратучы. *Шыркылдык кызларны егетләр ярата*

**2.** *и. мәгъ.* Шундый кеше. *Ул тегеләре шикелле шыркылдык түгел шул, ихахайга бик бирелми, уйчан кыз.* Ш.Маннур. *Савымчыларның берсе, олырак яшьтәге хатын, --- иптәшләрен шелтәләп алды: – Житәрегез сезгә, шыркылдыклар! Авыз җырырга гына торалар!* Л.Ихсанова

**ШЫРЛАНУ** *ф. гади с.* Үзен тәртипсез, әдәпсез тоту; кыланчыклану. *Хатын-кызның шулай шырланып, ирләрчә киенеп йөргәнен җенем сөйми минем.* Г.Гобәй

**ШЫРЛА́У** *ф.* Кычкырып, шаулап, шаркылдап көлү. *Бер-берләрен төртешеп Шырлап көләләр дә, Чыгарып телләрен, Бу, диләр, шашкан, юләр.* Һ.Такташ

2) Ашыгып, кабаланып, шаулашып тәртипсез һәм ашыгыч хәрәкәт итү. *Тавыклар шырлап качалар, куркып келәт астына тыгылалар.* М.Әмир

3) Шаулап, гөрелдәп, тавышланып, шарлап агу. *Шырлап ага торган чишмәдән салкын суны алып, минем юл чәйнегемә салып, ут ягып чәй кайнаттык.* Г.Исхакый. *Кайдадыр, шырлап, кечкенә елгамы, яисә арыкмы ага.* Р.Сибат

**ШЫРЛЫК** *и.* Урманда, әрәмәдә агачларның куе булып, ботаклары бербереләнә аралашып үскән урын; ешлык, куаклык, чытырманлык. *Авыл халкы урманның иң ерак, иң аулак шырлыкларын, чокыр-чакырларны, елга-күл тирәләрен айкап чыккан.* А.Гыйләҗев. *Ходайның бер бирмеш көнендә Абуталип эт тавышы килгән якка урман шырлыгына кереп китте.* З.Мурсиев

**ШЫРПЫ** *и.* 1) Бер башына күкерт катнашмасы сыланган таякчык рәвешендәге, күкертле нигезгә яки башка өслеккә сызгач, тиз кабынып китүчән ут алу кирәк-ярагы. *Кемдер шырпы сызып җибәрде һәм шундук коты алынып аһылдап куйды.* Н.Фәттах. *Шул тирәләрдә шырпы фабрикалары булган.* Р.Корбан

2) Тәнгә кергән, тәнгә кадалган агач чүбе. *Ул Аюның аягына шырпы кадалган икән, ди.* Әкият. *Гөлсирин дә аягындагы босоножкиен салып кулына алды. Ләкин озак баралмады – аяк табанына беренче шырпы кадалуга, ук аны кабат киеп куйды.* Х.Ибраһим

3) Аяк киеменә олтан салганда кулланыла торган, каты агачтан бер башы очлап ясалган кечкенә агач кадак. *Сәет карт өстәл янында ниндидер бер итекнең табанчасына шырпы кага.* Ф.Сәйфи-Казанлы // Торыпша башларын беркетү һ.б.ш. эш өчен бер башы очланган озын агач кадак. *Бакча коймасыннан сикергәндә такта башына эләгеп умырылып чыккан ыштан төбемнең ямавын шырпылар, күгәргән кадаклар табып эләктереп куйдым.* Г.Гобәй

4) Кайбер үсемлек сабагындагы үткен очлы үсенте, чәнечке, энә. *Кызгылт кара җимешләр белән бизәнгән көяз куак, үзен таптаган кешене өнәмичә, йөз дә бер шырпысын тәнгә кадады.* Н.Гыйматдинова // Кайбер хайваннарның тиресендә үскән чәнечкеле, каты кыл, энә

5) *күч.* Ут, янып торган шундый таякчык уты. *Шырпы яктысында аның ачу белән янган күзләре, калын, көчле уч төпләре күренеп алды.* М.Мәһдиев. *Шырпы утында шешенгән йөзләр күзгә чалынып калды.* Х.Камалов // Ут төртү, махсус оештырылган янгын. *Кулак шырпысыннан авылларда һәлак булган колхоз йортларын, игеннәрне Теге йомры башлы түрәләр, Хулиганнар эше диеп күрәләр.* Һ.Такташ

6) *күч.* Хуҗалык итүдә кирәкле вактөяк нәрсә. *Аркамдагы таудай йөкләр – Буш савытлар, буш яшникләр: Бушаганнар... бурычлардан. Эшкә биргән сулышлардан. Алмыймын бер шырпысын да, һәммәсен калдырып китәм.* С.Кудаш

7) *күч.* Рухи газап китерә торган нәрсә, күңелне тырнап торган хис. *Ышна җире әле һаман авылның йөрәгенә кадалган шырпы булып тора икән.* И.Гази. *Аларның өйләренә яңадан бәхет керде, шатлык кайтты, алар тагы елмая, бер-берләренең күзләренә карый ала башладылар. Әмма Камилнең күңелендә барыбер бер шырпы, җәрәхәт калды.* Ф.Бәйрәмова

◊ **Шырпы белән уйнау** 1) Янгын куркынычы тудыру; ут белән уйнау. *Өйдә үзе генә калган дүрт яшьлек Рөстәм шырпы белән уйнап ут чыгарган.* Акчарлак; 2) Хәтәр эшкә керешү, зур куркыныч тудыру. **Шырпы булып кадалу** Күңелнең иң нечкә кылларына тию, рухи газаплау, бик нык әрнетү. *«Бала» дигән сүз йөрәгенә шырпы булып кадалды.* Х.Камалов. --- *нәкъ менә Фидаяның бәгыренә шырпы булып кадалган Мирхуҗин турында сүз башлады.* М.Маликова. **Шырпыга да кагылмау** 1) *к.* **шырпыга да тимәү**. *Үсмер иске кепкасын кулы белән угалап торды да: – Минем өчен иң изге кешеләр – әнием, әтиемнең рухы белән ант итәм: башка беркайчан да, сорамыйча, кешенең шырпысына да кагылмаячакмын.* Т.Галиуллин; 2) Бер әйберне дә алмау. – *Кара әле, Фазылҗан кордаш, шуны беләсем килә: эшкә ат җигеп барсам әгәр, чыбык-чабык салгалап кайтырга мужны булыр микән? – Председатель Мөхсиновка килгәндә, ул мондый мәсьәләдә таш кебек каты иде. – Не смей шырпысына да кагылырга, – дип кычкырды ул ---.* Ф.Хөсни. *Ә менә коллективтан чыгарылып, шәхси хуҗалык алып бара башлагач, колхоз милкенең шырпысына да кагылырга хакың булмагач --- ай-һай, уйландыра икән ул.* В.Нуруллин. **Шырпыга да тимәү** Бик намуслы булу, сораусыз бер әйберне дә алмау, бервакытта да урлашмау. *Кешенең шырпысына да тимәгән Әхмәдиша нәселеннән карак килеп чыккан.* Т.Миңнуллин. *Кулыгыздан килгәнчә кешеләргә ярдәм итегез, йөзгә кызыллык китермәгез, кешенең шырпысына да тимәгез, дип өйрәтте ул безне.* Безнең гәҗит. **Шырпы да урламау** *к.* **шырпыга да тимәү**. *[Әнә карагы:] Гомеремдә минем әнә түгел шырпы да урлаганым юк, нигә миңа карак диләр?* А.Алиш. **Шырпы кадау** Кемгәдер чәнчүле, кинаяле, төртмә сүзләр әйтү. *Алар, бер-берсенә шырпы кадаша-кадаша, машина янына бардылар.* Х.Камалов. **Шырпы кебек (сыман) кабыну** Тиз ярсып чыгу, кызып китү. *Әнисе кайткач, Гөлгенә күзгә күренеп үзгәрде ич: сабыр гына кыздан шырпы кебек кабынып китә торганга әйләнде ---.* Ә.Сафиуллин. *Минем кимчелекләрем күп. Игътибарсыз, үзсүзле, кире дип әйтә алам үзем хакында. Шырпы сыман кабынам да тиз сүнәм.* А.Юнысова. *Мин кызу канлы кеше, шырпы кебек кабынып китәм.* Безнең гәҗит. **Шырпыны да калдырмау** Бернәрсә дә калдырмау, бөтенләй алып бетерү, тоташ чистарту. *Да, Муратовларның, нинди бай магазинның шырпысын да калдырмаганнар.* Т.Гыйззәт. **Шырпы очы кадәр** Бик кечкенә, бәләкәй; аз гына; инә очы кадәр. *Мортазаның күңелендә Вилен Канчуровка карата шырпы очы хәтле дә җылылык юк һәм булуы мөмкин дә түгел.* М.Ма-

ликова. **Шырпы санау** *этн.* Аулак өй уенында үбеш. **Шырпы тартмасы кебек (шикелле, кадәр, хәтле)** Бик кечкенә. *Шырпы тартмасы хәтле ак ипи эләксә, шуның белән көне буе тук йөри.* А.Хәсәнов. *Дәү әнисе кибеттән шырпы тартмасы кадәр генә сырок алып чыкты ---.* И.Юзеев. *Өзлексез йөреп торган автомобильләр, автобуслар, трамвайлар шырпы тартмалары шикелле кечкенә генә булып күренәләр.* А.Шамов. *Аның өендә гармуннарның шырпы тартмасы кебекләре дә бар!* Р.Рахман. **Шырпы сызу** Коткы салу, котырту; корткычлык итү. *Безнең эшкә шырпы сызучылар Юкка гына бәйрәм итәләр.* М.Җәлил

**ШЫРПЫЛАНУ** *ф. күч.* Кемгә дә булса тел белән, сүз белән начар тәэсир итү, күңеленә тию, кадау. *Яшь килен дә мунча чыгуга җае белән кайнанасына шырпыланып алды.* М.Мәһдиев

**ШЫРПЫЛА́У** *ф.* Нәрсәне дә булса агач шырпылар ярдәмендә эләктереп, беркетеп кую. *Сушилкага кайтып җитсәм – малайлар минем йөкне дә төяп бетергәннәр, чыбылдыкны шырпылап, кабыкларны бәйләп торалар иде.* А.Гыйләҗев

**ШЫРПЫЛЫ** *с.* **1.** 1) Шырпылары (*2, 4 мәгъ.*) булган, кадала торган, чәнечкеле. *Минә күпер. Шырпылы култыксалар.* А.Гыйләҗев. *Хәтердә калка әремнәр, Шырпылы билчәннәре.* Н.Әхмәдиев

2) *күч.* Күңелне җәрәхәтли торган, йөрәккә кадала торган. *Бикбулат картые Шаһ-Солтаннан фәкать төртмә сүзләр, шырпылы кинаяләр генә ишетсә дә, шул төртмәләрдән, шул кинаяләрдән еш кына үзен борчыган көеккөенечләргә җавап та таба иде.* М.Әмирханов. *КПССның Чадыр-Лунга райкомы икенче секретаре Кирилл Валентирның безгә күрсәткән хәйран җилле һәм шырпылы мөнәсәбәте әле дә хәтердә.* Т.Әйди

3) *күч.* Усал, үзсүзле, кире, үҗәт. *Җайсыз егет! Энәле егет! Шырпылы егет! Мин нишләргә тиеш инде, синеңчә?* А.Гыйләҗев. *Бер танышы төш күргән дә Котбетдингә сөйли икән: – Төшемә бөтенләй үз холкың-гадәтең белән кердең инде, һаман шулай шырпылы...* Ш.Галиев

4) *күч.* Кинаяле, чәнечкеле, төртмә. *Рәмисә Таһиянең --- кайнарланып акыл сатуларына шырпылы теле белән салкын су сибә.* Х.Камалов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Төртмәле итеп, төрттереп. *Шөреп Регинаны биергә чакырды. Шырпылы сөйләшсә дә, ялындырып тормады. Күптәнге танышы төсле, кулларын егетнең җилкәләренә куйды.* Т.Галиуллин

2) Киреләнеп, үҗәтләнеп. *Сәфәргали бу сүзләрне уйнап кына әйтте, ләкин уйлап әйткәннән болайрак чыкты: Тәлгатьнең шулай шырпылы торуы аны кинәт сискәндергән иде.* Ф.Хөсни

◊ **Шырпылы Шәми** Усал телле, кешегә һәрвакыт төртмә сүзләр әйтүче кеше турында

**ШЫРПЫТЕЛ** *и.* Кинаяле, чәнечкеле, төртмә телле кеше. *Хатынның усал, шырпы теленә дә «дару» табыла.* Т.Галиуллин

**ШЫРСЫЙ** *с. диал.* Җиңел холыклы, ваемсыз, һәр нәрсәгә җиңел караучан. *Әле дә ярый дөньяда дураклар күп, югыйсә минем нише шырсыйрак тегүче ничек яши алыр иде.* Ф.Хөсни

**ШЫРТ** I *иярт.* Әйбер сынган, өзелгән яки бәрелеп чатнаган һ.б. чакта чыккан кыска саңгырау тавышны һәм кисәк сыну, өзелү рәвешен белдерә. *Аяк астында шырт та шырт кипкән ботаклар сына ---.* Н.Гыйматдинова. *Инде ялтырап килеп чыга дигәндә... шырт – өзелде кармак җебе. Китте балык!* С.Зыялы

**ШЫРТ** II *и.* **1.** 1) Дуңгыз сыртында үскән озын каты кыл. *Йомры-йомры туп кебек, Бөтен тәне шырт кебек.* Табышмак.

2) Кыл кебек каты, тупас, тырпаеп торган чәч (гадәттә сакалда). *Әле ярый юынып чыктым. --- Югыйсә чәч шырт ише катканые.* Ә.Гаффар

3) Җитен сүсен тарау, тетү өчен махсус тарагыч, эре тешле тәрәшле тарак. *Җитен сүсен шырт белән тарау*

**2.** *с. мәгъ.* Кыл кебек каты, тырпаеп торган. *Күк төтеннәр ягыннан киләм, шырт камыллар гына бар тирәм.* Р.Әхмәтҗан. *Әй, Бакиров, танышыңмы бу шырт чәчне? Якташың икән ләбаса.* Ә.Хәкимов

**ШЫ́РТ ИТҮ** *ф.* Шыртлау, саңгырау шырт иткән тавыш чыгару. *Ул --- дача йортлары арасыннан узды да яшь бер алмагачның сусыл ботагын шырт итеп сындырып алды.* Г.Сабитов

**ШЫРТЛАВЫК** *с.* **1.** Шыртлый торган, шыртлап тора торган

**2.** *и. мәгъ.* 1) Ике кисәктән торып, берсе икенчесенә кереп берегә торган металл яки пластмасс каптырма. *Блузкага шыртлавык тагу*

2) *к.* **шыртлавык коңгыз**. *Чи йомырка кабыгын кулланып та шыртлавыкларны юк итеп була.* Мәйдан

**ШЫРТЛАВЫ́К КОҢГЫЗ** *и. зоол.* Шыртлавыкчалар семьялыгыннан аркасына әйләндергәндә шырт иткән тавыш чыгара торган корткыч коңгыз; *русчасы:* **жук-щелкун**. *Чебеннәр, афодийлар һ.б. урынына тире-йон коңгызлары (кожееды), шыртлавык коңгыз личинкалары (проволочники), безелдәвек коңгызлар (жужелицы) килә.* Ә.Халидов

**ШЫРТЛАВЫ́КЧАЛАР** *и. зоол. күпл.* Озын очлаеп торган гәүдәле, кыска аяклы, үсемлек азык белән туклана торган коңгызлар семьялыгы

**ШЫРТЛАКА** *и. зоол.* 1) Алабугалар семьялыгыннан сырты кара тимгелле, соргылт яшел, ян-яклары саргылт, корсагы ачык соры яки ак төстәге, төче сулыкларда яши торган чәнечкеле канатлы вак балык; кыртыш; *русчасы:* **ёрш**. *Өйдә ятсаң, бәхетең артыр, бетмәде инде балыгың, тота алсаң иде ичмасам, кашык буе өч шыртлака өчен көне буе интегәсең.* А.Гыйләҗев. *Хәзер ничектер, ләкин ул елларда Казан елгасында алабуга, чабак, кушбаш, шыртлака, сирәгрәк булса да, чуртан кебек балыклар була иде.* К.Гыйззәтов

2) *к.* **шыртлавык 2.** *Укытучы хатын --- киемнәрен эзли. Капронын ак мәрмәр ботларына киде, шыртлакаларына эләктерде.* Х.Камалов

**ШЫРТЛАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **шыртлау**

2) Шырт иткән тавыш чыгару. *Ул нәкъ шушы җөмләгә басым ясарга теләгәндәй тын калып, тагын планшет кнопкасын шыртлатырга тотынды.* М.Насыйбуллин. *Малай-шалай шыртлаткан чыбыркы очыннан чәчрәмидер бит ул алай-болай?* Н.Гыйматдинова

2) *күч. к.* **шыттыру** (*2 мәгъ.*). *Эләккән бит Тиктормаска Минә мондый шыртлака! Беләм инде, сез әйтерсез: «Шыртлата бу, шыртлата...»* Х.Гайнетдинов

**Шыртлата башлау** Шыртлатырга тотыну

**Шыртлатып алу** Тиз арада шыртлату; аз гына шырлату. *Монда без дә кул кушырып утырмадык – һәм ул планшетының кнопкасын берничә тапкыр баскалап шыртлатып алды.* М.Насыйбуллин

**Шыртлатып кую** Кинәт кенә, бер мәртәбә шыртлату. *Ул үкенечле итеп телен шыртлатып куйды.* Г.Гобәй

**Шыртлатып тору** Әле, хәзер шыртлату; даими яки әледән-әле шыртлату

**ШЫРТЛА́У** *ф.* Шырт иткән тавыш чыгу, саңгырау шартлау авазы чыгу, шырт итү. *Ләкин ни сәбәптәндер шул мизгелдә ук үзе как идәнгә барып төште, калак сөякләренең шыртлаганын ишетте ---.* М.Кәбиров. *Шул – вакыт күлнең икенче ярында, яр буенча куе булып үскән кыяклык арасында, шыртлап агач сынган, кеше йөргән тавышлар ишетелде.* Х.Ибраһим

**Шыртлап китү** Кинәт шыртлау. *Аркадагы грузчик «мендәренә» бер капчык тозны китереп салган чакта, умырткалар шыртлап китә, аяк астындагы басмачалар сыгылып килә.* Р.Фәйзуллин. *Андый ачуланышуның иң озын срогы өч көн, медицина телендә ул «бытовая травма». Ул уза да китә, ул – капчык күтәргәндә муен шыртлап китү белән бер.* М.Мәһдиев

**Шыртлап кую** Кинәт кенә бер тапкыр шыртлау. *Киеренде Шәмси куллары белән – аяклар сузылмады. Умыртка шыртлап куйды...* Ж.Юныс. *Үгезләр елдам гына атлый, олау буразна саен ава-түнә чайкалып, шыгырдап, шыртлап куйгалый.* Ю.Бондарев

**ШЫ́РТ-ПЫРТ** *рәв.* Тиз генә, кыска вакыт эчендә, ашыгыч рәвештә. *Малайларның да вакыты юк барып килергә. Оныкларның берсе шырт-пырт барып килеп йөри дә Кавказ иленә, тыңламый бит гозерне.* Т.Миңнуллин

**ШЫ́РТ-ШЫРТ** *иярт.* Нечкә чыбык-чабыклар сынгалап, каты әйберләрне кимергәндә, вак нәрсәләрне ватканда, таптаганда һ.б. чыккан өзек-өзек тавышны белдерә. *– Яшь чагында токалый идем мин бу каһәрне! Хәзер онытылган. Тончыктырды, шайтан, – диде ул, шырт-шырт суган чәйнәп.* А.Гыйләҗев. *Зифа буйлы яшь каеннарның әле сусыллыгы бетмәгән ботакларын шырт-шырт сындыра-сындыра, алар читкәрәк юнәлделәр.* Ш.Маннур

**ШЫ́РТ-ШЫРТ ИТҮ** *ф.* Шундый тавыш чыгару. *Шырт-шырт итеп изелделәр бармаклар ---.* К.Кара

**ШЫ́РТ-ШЫ́РТ КИЛҮ** *ф. к.* **шырт-шырт итү**. *Әгәр тиз арада моннан үкчәңне ялт иттермәсәң, сөякләреңнең шырт-шырт килүен рәхәтләнеп үзең тыңларсың.* Г.Мөхәмматшин. *Бармак төпләре шырт-шырт килде.* Б.Камалов

**ШЫРЧӘЙ** *и. фарс.* Чәйне сөттә пешереп, шуңа тоз, борыч һ.б.ш. кушып ясала торган эчемлек

**ШЫ́Р-ШЫР** *иярт.* **1.** Кеше яисә берәр хайван ямьсез итеп кычкырганда чыккан тавышны белдерә. *Аракысын күтәреп, хатын-кыз шүрәлеләр артыннан куып йөри, тегеләре шыр-шыр кычкырып кача.* Ф.Яруллин. *Соңгы приём вакытында моңа кадәр шыр-шыр акырган кызым елау турында уйламады да.* Сабантуй

**2.** *рәв. мәгъ.* Шаркылдап, шаулап, тавышланып. *Алар аулакта, кызларны мыскыл итеп, әлләниләр сөйлиләр, шыр-шыр көләләр.* Л.Таналин

**ШЫРЫЙЛАП** *рәв.* Ямьсез ачы тавыш белән, шыр-шыр итеп. *Башта куелыкта шырыйлап кычкырган, елаган тавышлар ишетелде.* М.Мәһдиев. *Бераздан өстәлдәге будильник шырыйлап шалтырарга тотынды.* Х.Камалов

**ШЫРЫ́Й-ШЫРЫЙ** *иярт. к.* **шыр-шыр**. *Чәбәләнеп, шырый-шырый акырып, укытучыга әләкләүче кызчыкларның гына чәчен тартып уйнау кызык икән ул...* Ватаным Татарстан

**ШЫРЫ́ККА** *рәв.* Әрәмгә, юкка, бушка, кирәксезгә; начар якка, күңелсез юнәлешкә. *«Ярар, без эшне шырыкка җибәрмәскә тырышырбыз», – дип, үземне юаттым.* Н.Акмал. *Район башлыгы вәгъдәсе белән бер бина төзеп, аннары шуның өчен акча ала алмыйча чиләнгәннән соң, эшләре шырыкка китә аларның.* Акчарлак

**ШЫРЫ́К-ШЫРЫК** *иярт.* Тыела алмыйча, туктасыз кычкырып көлү тавышын һәм рәвешен белдерә. *Самат бик кызык нәрсә сөйли иде, ахрысы, Фәридәсе шырык-шырык көлә.* Г.Галиева. *Ә артистлар, тамаша күзәтергә җыелган бала-чага сыман, аларны уратып баскан да, бер ишесе шырык-шырык көлә, бер ишесе тегеләрнең йодрыгына көч-куәт өстәп кычкыра ---.* Н.Гыйматдинова

**ШЫРЫЛДАП** *рәв.* 1) *к.* **шырыйлап**. *Куе үлән өстенә ятып аунады, юлдашларына су чәчрәтеп шаярды, үзенә салкын тамчылар килеп тигәч, шырылдап, бөтен үзәнлекне яңгыратты.* Т.Әйди. *Нуяк куркудан шырылдап акырып җибәрде.* Р.Батулла

2) Мул итеп, зур агым белән, көчле агым булып; тавышланып. *Әмма аты хуҗасыннан да битәр сусаган иде. Башын чиләккә тыгып шырылдап чөмерә генә.* Н.Дәүли

3) *куч.* Дәррәү, барысы бердән. *Башыбыз иләк кебек, барысы шырылдап коела.* Г.Әпсәләмов

**ШЫТ** *и. к.* **шырт** II. *Коелган башаклар махсус ясалган атлы җиңел агач тырмалар белән җыелып, башаклы озын арышлар урынына шыт кебек тырпаеп торган чип-чиста коры камыллар гына басып калалар.* М.Гали

**ШЫТТЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **шыту**. *Тотындым шуннан соң борчак шыттырырга. Әй шыттырам борчак, әй шыттырам...* Л.Лерон. *Клубка бәрәңге салды колхоз, шыттырырга; сәхнәгә ашлык җәйделәр киптерергә.* М.Яһудин

2) *куч.* Берәр хәл, күренеш турында үзеннән ялган кушып, күпертеп, арттырып, булмаганны өстәп сөйләү. *Лиза хәтта, Нурый шыттырмаган булса, аны бернichә мәртәбә иренennән дә үбеп алган икән.* Р.Мөхәммәдиев. *Ә аны үз башыннан үткәргәннәрнең берсе, ну, егет, шыттырасың да инде, дияр, ә икенчесе, кеше ышанмастай сүзне чын булса да сөйләмә, дияр, өченчесе исә, аны ярты юлда ук бүлеп, алдакчы дигән ярлык тагарга да күп сорамас.* Р.Кәрами

**Шыттыра башлау** Шыттырырга тотыну. *Шыттыра башлады, дим эчемнән генә. Кемнең абыйсы булмас та, кемнең туган апасы булмас.* Р.Рахман. *Хатын-кызлар инде болгар борычын, башка яшелчәләрне, кайбер чәчәкләрен шыттыра башласа, ир-егетләр алда торган яз-көз айларына төзелеш объектларын хәстәрли ---.* Кызыл таң

**Шыттырып алу** Бераз, тиз генә шыттыру. *Бакчачылар бәрәңгене утырткачы берникадәр шыттырып ала һәм күзәнәк җибәргәч утырта.* Кызыл таң

**Шыттырып җибәрү** Мөмкинлектән файдаланып кинәт шыттыру. *Егетләргә сөйләгәндә, шофёр бераз гына үзеннән өстәгән иде. Ә егетләр, Барыйга сөйләгәндә, шулай ук бераз гына арттырып, шыттырып җибәрделәр.* Н.Фәттах. *Кешедә кызыксыну уятасың килсә, бераз шыттырып та җибәрергә кирәк.* Р.Нуруллин

**Шыттырып карау** Тикшерү-белү максаты белән шыттыру. *– Кышлаган орлыкларны шыттырып карау, өстәлгә фәкать баллы ризыклар гына кую, болар барысы да яхшы уңышка ишарә ясау инде, – дип сөйләде үз әңгәмәсендә --- профессор Рәфис Хәсән улы Шәймәрданов.* Сөембикә

**Шыттырып кую** Бераз, бер тапкыр шыттыру; алдан шыттыру. *Мәдәниятле кеше хөрмәтенә, гадәттәгечә, әз генә*

*шыттырып та куйды: – Бу – фән тарафыннан расланган. Тучны әйтәм мин сезгә.* Ф.Садриев

**ШЫТУ** *ф.* 1) Үсенте яралгы орлык кабыгын төртеп чыгу, үренте бирү; җир өстенә тишелеп чыгу, җир өстендә үсемлек яралгысы үсеп чыгу. *Менә берничә көннән арыш шытып чыгар.* М.Мәһдиев. *Борчаклар тишелеп чыкты, әнисләр шытты, чөгендер шаулап үсте.* Р.Батулла // Яңа чыга башлау. *Мыегы яңа гына шыта башлаган сержант шалтыр-шолтыр итеп йозакны ачты.* Р.Зәйдулла

2) *күч.* Барлыкка килү; формалашу; иҗат ителү. *Җырларым, сез, шытып йөрәгемдә, Ил кырында чәчәк атыгыз!* М.Җәлил. *Мирхасның башында берничә план шытты.* Х.Камалов. *Күңеленнән яңадан-яңа матурлык бөреләре шытып чыксын.* Ф.Яруллин

**Шыта башлау** Шытырга тотыну. *Табигатьтәге кебек, татар халкы тормышында да яшь үсентеләр инде шыта башлаган ---.* М.Галәү. *Хәзер минем йөрәктәге ят хис тойгысыннан шыта башлаган яшәеш чиясенең төше ярылып китеп, борын төртәчәк ---.* Ф.Яхин

**Шыта тору** Шытуын дәвам итү; бербер артлы шыту. *Алар җыры илем гамендә, Намус дымы бәхет биргәнендә Шыта торды орлык хәлендә.* Ф.Яхин

**Шытып килгән** Акрынлап, азазлап шыту. *Мәчет картларыннан берикесе яңа гына шытып килгән яшел чирәм өстеннән шунда таба атлап киттеләр.* К.Нәҗми

**ШЫТЫМ** *и.* 1) Орлык яралгысыннан чыккан беренче үренте, үсемлекнең җир өстендә күренгән иң беренче яшь сабагы. *Менә чүп арасыннан сиреньнәрнең яшь шытымнары килеп чыкты ---.* А.Гыйләҗев. *Икенче көн таңында бодай кырында күгелҗем ятьмә күренде. Бу ни бу? Бу бит бодай шытымнары шулай күгелҗем! Күрегез, орлыклар тирәннән шытып чыккан!* Р.Хисмәтуллин

2) *күч.* Хезмәт, тырышлык, акыл, сәләт белән зур көч куеп яулап алынган уңыш, казаныш; эшнең нәтиҗәсе. *Г.Буби чәчкән орлыклар мул шытым бирә, ул оештырган мәктәптә тора-бара сигез йөзләп бала урта белем ала башлый.* Т.Әйди. *Менә берчак, тоталитар режим тетрәнеп китеп, җәмгыятьтә демократик шытымнар күренә башлаган ---.* Р.Фәйзуллин

**ШЫТЫР** *иярт. к.* **шытырт**

**ШЫТЫРДАП** *рәв.* 1) Бик нык, каты; шакыраеп. *Яртылаш лай утырган батареяларның илле проценты шытырдап каткан булып чыкты.* А.Гыйләҗев. *Беатриса тутәй --- мич башыннан шытырдап кипкән әрдәнәләр алып, титанга якты.* Г.Мөхәммәтшин. *Мең тугыз йөз җитмеш җиденче елның җәе ифрат коры килде, эсселектән игеннәр шытырдап көйде.* М.Зарипов

2) Тагы да ныграк, дөрләп. *План шытырдап яна.* А.Гыйләҗев

**ШЫТЫРДАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **шытырдау**

2) Шытырдаган тавыш чыгару. *Безнең балалар да сугышлы уйный. Автомат, пистолет шытырдаталар.* Ш.Галиев. *--- әнә ул, гомердә булмаганны, шытырдатып тозлы кәбестә ашый!* М.Мәһдиев

3) *к.* **шыкырдату**. *Дембел, дип, Әкрәм ачудан тешләрен үк шытырдатып алды.* Р.Сәгъди

**Шытырдата башлау** Шытырдатырга тотыну

**Шытырдатып кую** Бер тапкыр шытырдату. *Һади, еш-еш сулыш алып, тешләрен шытырдатып куйды.* М.Хәсәнов

**Шытырдатып тору** Әле, хәзер шытырдату; даими яки әледән-әле шытырдату

**ШЫТЫРДАТЫП** *рәв.* 1) Нык иттереп, бик каты иттереп, чытырдатып. *--- мин, шытырдатып, тешләремне кыстым, күзләремне йомдым, ике кулым белән караватка тотындым.* И.Юзеев. *Озынча кушеткага егып салдылар да күз ачып йомганчы шытырдатып бәйләп куйдылар.* Г.Галиев

2) Ачык, аңлаешлы итеп, чатнатып. *Зәйнулла хаҗи --- хатны укыгач, --- Мөхәммәтханны җентекләп карады: – Яза беләме? – Белә иде, төркине шытырдатып укый, гарәпкә төшеп калган иде.* К.Тинчурин. *Рафуш --- хәзер, шытырдатып, ике телдә сөйли.* Һ.Такташ

3) Кызганусыз, аяп тормыйча. *Баш мөхәррир Нияз ---: – Теге чакта синең миеңә каты суккан икән шул, әле һаман айнымагансың, – диде ул һәм «иҗат җимеше»н шытырдатып ертты да чүп савытына томырды.* Н.Гыйматдинова. *Ул сүз миңа ишетелгән чакта Агулы иде. Күкрәк, тын кысты. Исемлектән түгел, күңелемнән Шытырдатып сыздым ул дусны.* Х.Камалов

4) Үз ихтыярыңнан, теләгеңнән башка, мәҗбүр булып. *Телисеңме, теләмисеңме, имзаңны шытырдатып куй[дыра].* Н.Дәүли

5) Икеләнмичә, хаклыгына ышанып. *Кәгазьләремне игътибар белән карап чыкты да, «Йортын урынында калдырырга!» дип язып, шытырдатып имза куйды!* Ф.Баттал

6) Бар көченә. *Альяпкычын чишеп тә тормады шикелле, шытырдатып йолкып алды да каядыр тыгып куйды.* Д.Бүләков

**ШЫТЫРДА́У** *ф.* Шытыр-шытыр килү, шытыр-шытыр иткән тавыш чыгу, шундый тавыш чыгу. *Әнисе нидер әйтте, әмма аңларлык түгел, телефон шытырдый, бер өзелә, бер ялгана иде.* Ф.Садриев. *Фәнисә инде кереп китәм дигәндә генә, бакча түрендә гөрселдәгән һәм агач ботаклары шытырдап сынган тавышлар ишетелә.* З.Хәким

◊ **Шытырдап торган** 1) *к.* **шыгырдап торган** (*1 мәгъ.*). *Барый малайларга түш кесәсеннән шытырдап торган ике йөзәрлек чыгарып бирде.* З.Хөснияр. *Өстемдә үтүкләнгән шәһәр чалбары, җете ак күлмәк, ә аягымда шытырдап торган көрән күнле яңа сандалилар иде.* Т.Нурмөхәммәтов; 2) *к.* **шыңгырдап торган**. *Икенче йорт шытырдап торган нараттан салынды.* Р.Батулла

**Шытырдап алу** *к.* **шытырдап кую**. *Ул арада багана башындагы көчәйткеч шытырдап алды ---.* Н.Әхмәдиев. *Телефон тагын шытырдап алды.* Р.Вәлиев

**Шытырдап китү** Кинәт шытырдау. *--- алар рәтләп сөйләшергә дә өлгермәде, кинәт бөтен бүлмәләрдә репродукторлар шытырдап китте.* Г.Әпсәләмов. *Озынъялның койрык төбе шытырдап китте.* А.Гыйләҗев

**Шытырдап кую** Бер тапкыр шытырдау, аз гына шытырдау. *Нәкъ шул вакыт Сабирҗан бакча буендагы иске читәннең шытырдап куюын ишетеп калгандай булды.* М.Хәсәнов. *Кинәт трубка шытырдап куйды һәм кемдер нәрсәдер әйтте.* И.Хуҗин

**Шытырдап тору** Әле, хәзер шытырдау; шытырдый торган булу. *Мин --- репродукторның төймәсен бордым. Нәрсәдер шытырдап торды, нәрсәдер кыштырдады, аннары куе, калын тавыш ишетелде ---.* Л.Ихсанова. *Шикләнәсе юк, җир коры, кипкән үлән шытырдап тора.* Ә.Хәсәнов

**Шытырдый башлау** Шытырдарга тотыну. *Кайвакыт шундый китереп кысалар, кабыргаларың шытырдый башлый.* М.Галәү. *Аерым көннәрдә тузан киемнәргә генә түгел, колакларга, авыз эчләренә кадәр тулып, теш араларында шытырдый башлады.* Ф.Садриев

**ШЫТЫ́Р ИТҮ** *ф. к.* **шытырт итү**. *Иртә генә мороз, кичтә – салкын. Шытыр да гына шытыр итәдер. Иркәләнеп үскән иркә башым Ирексез җирләргә китәдер.* Бәет. *Агачларның арасында берәр нәрсә шытыр итсә, Берәр чит нәрсә күрсә, яки бер кош очса, пыр итсә, – Тәмамән курка, сискәнә, дерелди, калтырый башлай ---.* М.Гафури

**ШЫТЫ́Р-ПЫТЫР** *иярт.* **1.** Өзек-өзек тигез ритм белән эшли торган нәрсә чыгарган өзек-өзек шартлаулы яңгыравык тавышны белдерә. *Шытыр-пытыр моторлы көймәләр үтә.* Ш.Галиев.

**2.** *рәв. мәгъ.* Бәрелеп-сугылып, ашыгып. *Әнә шытыр-пытыр сөяркәсе килеп җитте.* А.Гыйләҗев

**ШЫТЫР-ПЫТЫ́Р ИТҮ** *ф.* Өзек-өзек шытырдаган тавыш чыгару

**ШЫТЫР-ПЫТЫ́Р КИЛҮ** *ф. к.* **шытыр-пытыр итү**. *Шул чакта, шытыр-пытыр килеп, рациягә җан керде.* М.Хәсәнов. *Ул ишек төбендә шытыр-пытыр килеп утырган кино моторы янына басты.* Р.Бәшәр

**ШЫТЫРТ** *иярт.* Әйбер кинәт ертылганда, сүтелгәндә, чәрдәкләнеп сынганда һ.б.ш. очракларда чыккан тавышны һәм кисәк сыну, ертылу һ.б.ш. рәвешен белдерә

**ШЫТЫ́РТ ИТҮ** *ф.* Шытырт кебек тавыш чыгару. *Мөгезенә элеп кенә Чөйдә дә атты тыштан! Шытырт итеп кенә китте Трофейный мурт ыштан.* Ш.Галиев. *Тегесе, рәхмәт әйтеп, киеп куйыйм дисә, шытырт иткән тавыш – тунның җөе аерыла.* Безнең гәҗит

**ШЫТЫ́Р-ШЫТЫР** *иярт.* **1.** Берәр нәрсә шартлаганда, сынганда, ватылганда, ертылганда яки сүтелгәндә һ.б.ш. очракларда барлыкка килеп, тоташ яки әледән-әле чыккан тавышны белдерә. *Безнең якка чыга торган читәнне шытыр-шытыр сындырып, тишекләр ача башладылар.* Г.Исхакый. *Төнлә шытыр-шытыр нидер чәйнәгәнен әткәй ишеткән ---.* Ш.Галиев

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Ашыгып, тиз-тиз. *Гаяров куен кесәсеннән блокнот тартып чыгарды да шытыр-шытыр яза башлады.* М.Маликова. *Кульяулык, күзге, ирен буявы ишеләр арасыннан дару капларын аерып алды, шытыр-шытыр ачып, вак төймәләрне учына җыйды.* Н.Гыйматдинова

2) Каты итеп. *Кайсы кырын ятып сагыз чәйни, кайсы тәрәшле тарагы белән шытыр-шытыр чәч тарый, ике кыз тәрәзә яктысында баш карашалар ---.* А.Гыйләҗев

**ШЫТЫ́Р-ШЫТЫР ИТҮ** *ф.* Өзек-өзек, кабатлаулы шытырдау тавышы чыгару, шыдырдау. *Шытыр-шытыр иткән ят тавыш ишеткәч, тыңлап тордылар.* Г.Тукай. *Трубкада, бераз шытыр-шытыр итеп алганнан соң, көр тавыш ишетелде ---.* Р.Ибраһимов

**ШЫТЫ́Р-ШЫТЫР КИЛҮ** *ф. к.* **шытыр-шытыр итү**. *Рульне теге яки бу якка борган саен, бөтен кораб дерелди, нәрсәләрдер шытыр-шытыр килеп бер-берсенә ышкылалар һәм кинәт корабның тизлеге кими.* Р.Мостафин. *Трубка шытыр-шытыр килә.* Р.Бәшәр

**ШЫ́Ш-ПЫШ** *иярт.* **1.** Әкрен генә сөйләшкәндә чыккан тавышны белдерә; пыш-пыш. *Тракторны күтәргәндә, бөтен авыл белән шыш-пыш килеп: «Мәңге исерек булды, үзе дә котылды, мескен, инәсе белән кызы да котылды», – диештеләр.* Х.Мөдәррисова

**2.** *и. мәгъ.* Пышылдап, шыпыртлап сөйләшкән тавыш. *Була шундый чаклар, сәхнә тамашачының игътибарын кулдан ычкындыра. Тамашачылар рәтендә шыш-пыш артканнан-арта.* И.Рәмиев

**ШЫШТЫРДАТУ** *ф.* 1) *йокл. юн. к.* **шыштырдау**. *Без синең белән, иске яфракларны шыштырдатып, тын урман эченнән барабыз.* Н.Фәттах

2) Шыштыр-шыштыр килгән тавыш чыгару. *Седов яза торган кәгазенә шыштырдатып кул куйды да стенадагы кнопкага басты.* М.Хәсәнов

**Шыштырдатып куюо** Көтмәгәндә, кинәт, аз гына шыштырдату. *Шаян җил яр буе камышларын шыштырдатып куя*

**Шыштырдатып тору** Бертуктаусыз, өзлексез шыштырдату. *Атлар печән шыштырдатып тора*

**ШЫШТЫРДА́У** *ф.* Кәгазь, печән, салам, кипкән яфрак кебек нәрсәләргә кагылганда, өзек-өзек җиңелчә тавыш барлыкка килү, шыштыр-шыштыр килгән тавыш чыгу. *Кәгазь шыштырдаган тавышка атасы уянып китте ---.* Х.Ибраһим. *Каенлыкта, шыштырдап, сары яфраклар коелды.* Г.Якупова

**Шыштырдап алу** Аз гына, кыска гына вакыт шыштырдау. *Өстә, югарыда, иркәле җил исеп китте, кое авызына капланып утырган куе үләннәр кызганыч, бик кызганыч итеп шыштырдап алдылар.* Н.Фәттах

**Шыштырдап кую** Аз гына, бер тапкыр шыштырдау

**Шыштырдап тору** Даими, бертуктаусыз шыштырдау. *--- агачлар иксез-чиксез казакъ далаларыннан искән коры челлә җилләрен тоткарлый, әмма үзләренең яфраклары кибеп-куырылып, шыштырдап тора.* Р.Мирхәйдәров

**ШЫШТЫ́РТ-ШЫШТЫРТ** *иярт. к.* **шыштыр-шыштыр**. *Алар, билгеле, Батима карчыкның нәрсә әйткәнен аңламадылар һәм аякларына кигән озын итекләрен шыштырт-шыштырт атлатып китеп бардылар.* Н.Фәттах

**ШЫШТЫ́Р-ШЫШТЫР** *иярт.* **1.** 1) Үләннәр, яфраклар, кәгазь һ.б.ш. нәрсәләр бер-берсенә ышкылганда чыккан тавышны белдерә; чыштыр-чыштыр

2) Куе үләннәр арасыннан барганда, зур аяк киеме белән йөргәндә чыккан тавышны белдерә; чаштыр-чоштыр

**2.** *с. мәгъ.* Шундый тавыш чыгара торган. *Өсләрендә – коверкот костюм, кунычына еш кына финка хәнҗәр кыстырылган шыгырдавык күнитек, хәзер инде күпләрнең төшләренә дә керми торган шыштыр-шыштыр салкынча ефәк күлмәк булыр иде.* Р.Мирхәйдәров

**ШЫШЫЛДА́У** *ф.* 1) [с], [ч] авазлары урынына [ш] кулланып сөйләү

2) *күч.* Усал итеп, теш арасыннан гына, ачу белән сөйләү. *Күрше килене кайнанасына нәрсәдер шышылдый иде*

**Шышылдап алу** Кыска вакыт арасында, аз гына шышылдау. *«Исе китте, әйләндерә, имеш» дип, ачуыннан тагын бер кат теш арасыннан шышылдап алды ул.* Ф.Сәйфи-Казанлы

**Шышылдап тору** Озак вакыт дәвамында шышылдау

**Шышылдый башлау** Шышылдарга тотыну

# Щ

**ЩЕ́ПКИНЧЫ** *и.* М.С. Щепкин исемендәге Югары театр училищесын тәмамлаучы. *Һәм, ниһаять, Дүртенче студияне 1988 елда тәмамлап, янә бер төркем щепкинчылар театрга кайтты.* Р.Батулла

**ЩЁТКА** *и. рус* 1) Гадәттә яссы кысага кыл яки аны алмаштыра торган материалны тыгыз итеп беркетеп эшләнгән себерү, чистарту әсбабы. *Газинур, җиңнәрен сызганып, кулына кыргыч, щётка алып, бәйдәге атлар янына килде.* Г.Әпсәләмов. *Хатыны Гөлзадә ханым кыл щётка белән аның түшләрен, аркасын сыйпап чыга...* А.Тимергалин

2) *тех.* Электротехника җиһазларының хәрәкәтсез өлешләреннән хәрәкәт итә торган өлешләренә ток күчерә торган деталь. *Щётка төрләре*

3) Сапка беркетелгән тимерчыбыклардан гыйбарәт, барабан таякларын алыштыра торган уен коралы. *Щётка белән уйнау тавышы*

**ЩЁТКАЛАУ** *ф.* Щётка белән чистарту. *Тешләреңне яхшылап щёткалап ю.* К.Тинчурин. *Берәрсе ял төбен кашыса яки щёткалап йонын тараса, рәхәтләнеп тора, элеккечә тәнен җыермый.* Ф.Яруллин

**Щёткалап алу** Тиз генә щёткалау. *Костюмны щёткалап алдым*

**Щёткалап бетерү** Барысын да щёткалау

**Щёткалый башлау** Щёткаларга тотыну. *Ул салам эшләпәсен киеп куя, битенә ярты уч одеколон сибә, ларёк алдына куйган күн бүрекләрне, эш бияләйләрен щёткалый башлый.* Ватаным Татарстан

**Щёткалап кую** Алдан щёткалау

**Щёткалап тору** Һәрвакыт, гел щёткалау

**Щёткалап чыгу** Һәрберсен берәмберәм щёткалау, башыннан ахырына кадәр щёткалау. *Өйләдән соң базарга чыгарга уйлагач, Габделбасыйр бик тырышып купшыланды: бишмәтне өч-дүрт мәртәбә щёткалап чыкты, берәүдән каракүл бүрек алып торды, чыгып китәр алдыннан дүрт-биш мәртәбә көзгегә карады.* М.Мәһдиев

**ЩЁТКАЛАНУ** *ф. төш. юн. к.* **щёткалау**

**ЩЁТКАЛАТУ** *ф. йөкл. юн. к.* **щёткалау**

**ЩЁТКАЛЫ** *с.* Щётка куелган, щёткасы булган. *Өч щёткалы бу машина өч метр радиустагы территорияне чистартып бара.* Татарстан яшьләре. *Тышкы төзекләндерү комитеты мәгълүматлары буенча, көндез Казан урамнарында 339 юл хуҗалыгы эшчесе һәм 227 берәмлек махсус техника: 68 щёткалы трактор, --- 5 җәяүлеләр сукмакларын җыештыручы машина һ.б. эшләячәк.* Ватаным Татарстан

**ЩИ** *и. рус* Туралган кәбестә, кузгалак, шпинат һ.б.ш. яшелчәдән төрле тәмләткечләр салып пешерелгән итле шулпалы аш. *Өстәлгә чүлмәктә мичкә тыгып пешерелгән щи куелды.* Ә.Исхак. *Татарга щи да кирәкми, Татарга токмач кирәк!* *Ш.Галиев*

**ЩИТ** *и. рус* 1) *тех.* Электр үлчәү һәм контроль приборлар урнаштырылган такта; панель. *Гыйлаҗ, миңа әйләнеп карамыйча гына, ниндидер төймәгә басты. Кызыл, яшел кечкенә лампочкалар белән тулган щит гөжләп куйды.* М.Хәбибуллин. *Тралмейстер белән неводчы һәм тагын берничә матрос тралны сүтеп, планширга китереп салдылар, электр щиты янына бастылар.* Ф.Шәфигуллин

2) Берәр каты нигезгә, кысага беркетелгән плакат, лозунг һ.б.ш.; транспарант. *Бер зур кәгазь щит күтәреп бастыралар.* Ә.Баянов

3) Нәрсәне дә булса саклау, аеру өчен кулланыла торган калай, такта яки башка материалдан ясалган калкансыман җайланма. *Кар тоткыч щитлар. Юл щитлары*

4) Җыелма йортлар төзү эшендә стена кую, бүлмә бүлү, түшәм каплау өчен кулланыла торган әзер панель. *Эшчеләр посёлогының читтәге, финский дип атала торган щитлардан эшләнгән йортларында утлар да сүнмәгән иде.* М. Хәсәнов

5) *спорт* Баскетбол уенында кәрзин ныгытылган такта. *Щитка кадәр сикерү*

**ЩИТЛЫ** *с.* 1) Билгеле санда яки сыйфатта щиты булган. *Шулай ук Алексей Ивановичның турыдан-туры катнашында Биләрдә спорт комплексы, ә бистәнең беренче мәктәбендә балконлы һәм уникe щитлы заманча баскетбол залы төзелде.* Заря

2) Щитлардан төзелгән. *Щитлы йортның бите, йөзе булмый. Щитлы йортның ин зур кимчелеге – тәрәзә йөзлекләре булмавында.* М.Мәһдиев

# Ы

**ЫБЫ́Р-ЧЫБЫР** *җый. и. сөйл.* **1.** 1) Кече яшьтәге балалар, бала-чага. *Утрау шактый әчкәре, ыбыр-чыбыр гына керешле түгел.* А.Тимергалин. *Элгәреге елларны чаңгы ярышларына катнаша идем, быел аңа да бармадым, ыбыр-чыбыр йөрсен әйдә!..* А.Гыйләҗев

2) Бик үк кыйммәтле һәм әһәмиятле булмаган нәрсәләр; вак-төяк мәшәкать. *Ыгы-зыгы, ыбыр-чыбыр белән Ел артыннан шулай ел үтте.* Р.Гатауллин

3) *куч.* Җәмгыятьтә дәрәҗәсе, акылбелеме һәм абруе белән түбән торган кешеләр. *Бату хан ыбыр-чыбырга җавап сүзе кайтарып вакланмады. Үгәдәй белән Чагатайныкылар шикелле, арыслан-юлбарыслар ырлый башламады бит әле, алар өчен көч сакларга кирәк.* В.Имамов. *Ул заманнарда Фаддей кебек ыбыр-чыбыр гына түгел, Солтаннан станциянең өлкәнрәк хулиганнары да курка, гомумән, посёлокта чеченнар белән бәйләнешергә берәү дә атлыгып тормый иде.* Р.Мирхәйдәров

**2.** *с. мәгъ.* 1) Кече яшьтәге, яшь. *Егет бер көн эчендә Юлкотлының бөтен тирә-ягын йөреп чыкты, машинасына ыбыр-чыбыр балаларны төяп, әллә кайлардан үзләрен йөртеп кайтарды.* Ә.Еники. *Иң элек эшне ыбыр-чыбыр малайлар башлап җибәрде.* А.Гыйләҗев

2) *күч.* Вак-төяк, әһәмиятсез. *Нишләп безнең яңа Тукайларыбыз юк, һәм, янәсе, нигә җыен ыбыр-чыбыр шигырь язып йөрүчеләр күбәйде?* Б.Рәхимова. *Сәхнәдә дә, өйдә дә бергә булсагыз, мине дә ыбыр-чыбыр мәшәкатьләрдән коткарырсыз.* А.Әхмәтгалиева

**ЫБЫР-ЧЫБЫ́Р КИЛҮ** *ф.* 1) *к.* **ыгы-зыгы килү**

2) Бала-чага шаулашып уйнау, чабу, йөгерү. *Бермәл шулай су буенда балачага ыбыр-чыбыр килә.* Кызыл таң

**ЫБЫ́Р-ЧЫБЫРЛЫ** *с. сөйл.* 1) Шау-шулы, ыгы-зыгылы. *Очрашуда ыбыр-чыбырлы чыгышлардан туеп кайтып киттем: Гали ага белән иртәгә аерым очрашабыз, «Татарстан – Төркия» җәмгыятен тәкъдир итү мәҗлесендә.* Казан утлары

2) Кече яшьтәге, яшь яки дәрәҗәсе түбән булган. *Ыбыр-чыбырлы бала-чага да бу тәүлектә тынып тора.* М.Мәһдиев

3) Мәшәкатьле, четерекле, вактөяктән торган. *Заһит абый Такташныкы сыман сибелгән чәчләрен чөеп куя да әкренләп безнең ыбыр-чыбырлы дөньяга кайта.* Ш.Галиев. *Тирә-юньдә ник кенә бер тавыш ишетелсен дә, ник кенә бер җан иясе бу дөньяның ыбыр-чыбырлы икәнлеген искә төшерсен!* Җ.Юныс

**ЫГГЫ́-ЫГГЫ** *ы.* Теле ачылмаган яшь баланың сөйләшкән сыман тамак төбеннән чыгарган авазын белдерә. *Әти-әнисен күргәч, бишектә ыггыыггы дип сөйләшеп яткан кызлары очына-очына елмая иде.* Ә.Хәсәнов

**ЫГГЫ-ЫГГЫ́ КИЛҮ** *ф.* Теле ачылмаган яшь бала сөйләшкән сыман авазлар чыгару. *Баш бармагы белән чишмә үзәненә күрсәтеп, бала кебек, ыггы-ыггы килде.* Казан утлары

**ЫГЫ́-ЗЫГЫ** *и. сөйл.* **1.** 1) Ашыгулы, тәртипсез, шау-шулы хәрәкәт; әрлебирле йөгереш. *Мәйданда инде байтак кына кешеләр алышынды, ыгы-зыгысы гына бер дә кимемәде.* В.Имамов. *Кичке урамда мин япа-ялгыз идем. Кешеләрнең ыгы-зыгысы арасында берүзем.* А.Әхмәтгалиева

2) Мәшәкатьле, борчулы эш-хәл, көн дә кабатлана торган вак-төяк шөгыль. *Кайчак мин төрле мәшәкатьләргә уралып, тормыш ыгы-зыгыларына чумып яшәгән кешеләргә кызыгып куям.* Р.Галиуллин

3) Тынычсызлык, тәртипсезлек, гадәти тынычлык бозылган халәт, болганыш, чуалыш. *Бераздан өске катта гадәти булмаган ыгы-зыгы башлана: урыныннан кузгатылган авыр шкафлар, идәнгә гөрселдәтеп ташланган китаплар, елаган, борчылып пышылдашкан тавышлар ишетелә.* Р.Мостафин. *Гади поезд тирәсендә була торган ыгы-зыгыдан аермалы буларак, монда хәлләр ничектер шөбһәлерәк төсле тоелды яшь хатынга.* Р.Гаязетдин

**2.** *с. мәгъ.* Ыгы-зыгылы. *Телефонда һичнәрсә аңлый алмаслык шау-шу, ыгы-зыгы чак иде.* Г.Бәширов. *Бер дилбегә озынлыгындагы арада ниндидер ыгы-зыгы тавышлар булып алды да капылт тынды.* В.Имамов

◊ **Ыгы-зыгы кубару** Бергә кайнашып, буталып йөрү

**ЫГЫ-ЗЫГЫ́ КИЛҮ** *ф.* 1) Ашыгыч һәм тәртипсез рәвештә хәрәкәт итү, әрле-бирле килү. *Барысы да шулкадәр буш, ясалма иде – тирә-якта ыгы-зыгы килгән кешеләрнең билләренә таянган манекеннардан бер аермасы да юк кебек.* А.Әхмәтгалиева. *Өй эче иртәдән ыгы-зыгы килде, Булат бер керде, бер чыкты, үз-үзенә урын тапмады.* З.Кадыйрова

2) Ашыгып, кабаланып ни дә булса эшләү. *Михляев йортының ихатасында пешекчеләр ыгы-зыгы килде, чибәр татар кызлары самавырлар күтәреп йөгереште.* В.Имамов. *Атларын ашату чараларын күреп, намазга әзерлекләр үткәреп, ыгы-зыгы килделәр.* З.Зәйнуллин

3) Шаулау, гөрләү, шау-гөр килү. *Бер дә юкка килмик ыгы-зыгы. Кирәккә дә, кирәк түгелгә дә Оран сугып, әйт, кем нәрсә тапты?* К.Булатова

**ЫГЫ́-ЗЫГЫЛАНУ** *ф.* Ыгы-зыгы килү. *Нәгыймә карчык аның артыннан, кабаланып, ыгы-зыгыланып: – Хәзер эчәрсең, эчәрсең, чәй әзер, – дип кычкырып калды.* Казан утлары

**ЫГЫ́-ЗЫГЫЛЫ** *с.* 1) Шау-шулы, тынгысыз. *Каникуллар бетеп, Дилбәр янә Казанга китте, ыгы-зыгылы тормыш кабат үзенә бөтереп алды.* А.Әхмәтгалиева

2) Мәшәкатьле, борчулы, тынычсыз. *Бу арада эшнең дә рәте-чираты юк, кәнитил артыннан кәнитил туып тора, бигрәк тә төнге вахталар ыгы-зыгылы.* С.Сабиров. *Алда – тормыш мәшәкате, ыгы-зыгылы борчулар.* А.Вергазов

**ЫГЫ́Й-ЫГЫЙ** *ы. к.* **ыггы-ыггы**. *Алма чәчәккәем минем, Сөрмәле күзем! Ыгый-ыгый диюләрең, Елмаю-көлүләрең; Телең ачылмаган көе Хәйләле белүләрең!* Н.Әхмәдиев

**ЫГЫРДА́У** *ф. гади с.* Шыгырдау сүзе белән янәшә килеп, ризасызлык күрсәтү, нәрсәгә дә булса каршы килеп маташу яки зарлану мәгънәсен белдерә. *Ыгырдама, шыгырдама, киясемне киямен.* Мәкаль

**ЫГЫРДЫ́Й-ШЫГЫРДЫЙ** *рәв. сөйл.* 1) Авыртудан ыңгырашып, көчхәл белән. *Бабай, бөтен гомеренә ыгырдый-шыгырдый гына йөрсә дә, озын гомерле булды*

2) Теләмичә, авырлык белән, ялындырып кына; кыенлык белән, кыенсынып. *Тегермәнче яңадан йөз алтын сораган. Вәзир ыгырдый-шыгырдый анысын да түләгән.* Н.Исәнбәт

**ЫГЫ́Р-ШЫГЫР** *рәв. сөйл. к.* **ыгырдый-шыгырдый**. *Болар кечкенә генә сәүдәгәр булып баралар, акыртын гына тәрәккый итәләр. Кризислар вакытында ыгыр-шыгыр гына үзләрен саклыйлар иде.* Г.Исхакый

**ЫГЫ-ЫГЫ** *ы. к.* **ыггы-ыггы**. *Уяу ятса, карашын гел әнисеннән алмый, ыгыыгы дигән аваз чыгарып көлгән я тибенгән була.* В.Имамов. *Бишектән Нияз да мес-мес итеп яткан җиреннән: – Ыгыыгы, – дип тавыш бирә.* Т.Нәҗмиев

**ЫГЫ-ЫГЫ́ КИЛҮ ф. к. ыггы-ыггы килү**. *Малай барысын да белгәндәй ыгы-ыгы килде, күзләрен дә ачып тормыйча елмайды да --- яңадан тәмле йокысына чумды.* Р.Рахман

**ЫЖ** *иярт.* Сызгыруга охшаш кыска ыжлау тавышын белдерә. *[Рамил] Саниянe читкә чакырып китерде дә: «Язгы урманга барырга җыенасың икән, кызый. Беләсеңме, анда адым саен ыж-ж – зәһәр еланнар!» [диде].* М.Рәфыйков

**ЫЖБАН** *и. рус диал.* Кечкенә мичкәгә охшаган капкачлы савыт. *[Төшемдә] Сәхип әби белән урманда йөргән, аның ыжбаныннан чүпләп җиләк ашаган кебек булам.* С.Җәлал

**Ы́Ж-ВЫЖ** *иярт.* Зур тизлек белән, әле бер, әле икенче якка хәрәкәт итүне белдерә; выж да выж. *Җәйнең матур кояшлы көнендә умарта кортлары чәчәктән чәчәккә ыж-выж оча*

**ЫЖГЫР** *с.* 1) Бик көчле, ыжгырып торган. *Күз ачкысыз ыжгыр бураннарда әллә күпме юлчылар адашып үлде.* С.Поварисов

2) Зәмһәрир, ачы, үзәккә үтә торган. *Аны тышта коры йолдызлары белән шыгырдап торган күк йөзе һәм куяннарны сикертерлек ыжгыр суык каршылады.* А.Хәлим

3) Көр, җитез, атлыгып торган. *Ыжгыр ат*

**ЫЖГЫРТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **ыжгыру** (1–3 мәгъ.). *Кинәт лапас кыегындагы басылган иске саламны куптарып, агач башларын ыжгыртып һәм киртәгә элеп куйган керләрне очыртып, дымлы, көчле җил исеп китте.* Н.Фәттах. *[Әмир] Шакмагын машинадай ыжгыртып газаплана.* Ф.Яхин

2) Зур тизлек белән чабу, бик кызу бару, элдертү. *Кузовына кызыл кирпеч төягән «КрАЗ» Олы урманны ярып узган тигез асфальттан ыжгырта гына.* Казан утлары

**ЫЖГЫРТЫП** *рәв.* 1) Зур тизлек белән. *Без, баржа яныннан кузгалу белән, узышка чыккан чабышкы кебек шундук ыжгыртып, зур тизлектә китеп бардык.* С.Сабиров

2) *күч.* Җитез итеп, булдыклы рәвештә уңышлы, нәтиҗәле итеп. *Дамир аркадашым, шөкер, озак еллар ыжгыртып эшләп йөрде.* Г.Гомәр

**ЫЖГЫРУ** *ф.* 1) Ыжылдаган тавыш чыгару (машина, нинди дә булса техника тур.). *Болар килгәндә, вокзалның эче-тышы халык белән тулы – бар да йөгерә, кабалана, теге якта пыш-пыш локомотивның ыжгыруы ишетелә, һәрхәлдә, поездның китәргә торганлыгы ишетелә иде.* Г.Ибраһимов

2) Көчле итеп исү. *Мүге сирәкләнгән бүрәнә ярыкларыннан җил ыжгыра.* Н.Гыйматдинова

3) *күч.* Усал, тупас тавыш чыгару; сызгыру, ысылдау (елан, ерткыч җәнлекләр тур.). *Мәгарә эчендә усал еланнарның ыжгырганы ишетелә.* Ф.Яхин

4) *күч. сөйл.* Ямьсез тавыш белән, усал итеп кычкыру, зәһәрлек күрсәтү, җикеренү. – *Синең ишеләрне генә күп күргән инде, – диде ул, зәһәрле ыжгырып.* Н.Фәттах

◊ **Ыжгырып торган** 1) Көчле давыл кубарган (буран, җил тур.). *Усал ыжгырып торган буран тавышын күмеп, аның катгый, кырыс әмере яңгырады.* В.Имамов; 2) Бик яхшы, җитез, көр; атылып чабарга гына торган (ат тур.). *Кабан исемле авылга җитәрәк, ыжгырып торган аргамакларда нindидер зур түрә очрады.* А.Расих; 3) Бик көчле; үз көченде булган, сау-сәламәт. *Ыжгырып торган, җиң сызганып эшләргә тиешле кеше эш булмагач нишләргә тиеш?!* Ватаным Татарстан; 4) Явыз, һәрвакыт башкаларны рәнҗетә торган. *Әби янына, Миндар абыйларга барсам да, якты чырай күрүләр насыйп булмастыр, анда аждаһа сыман ыжгырып торган Хәмидә апа бар.* Казан утлары. **Ыжгырып тору** Нинди дә булса эш башкарырга, кая булса да барырга ашкыну, дәртләнү, атлыгу. *Кияү егетләре әзер, ыжгырып торалар.* А.Гыйләҗев

**Ыжгыра башлау** Ыжгырырга тотыну

**Ыжгыра бирү** Теләсә нинди очракта да ыжгыруын дәвам итү

**Ыжгырып алу** Бераз, кыска вакыт арасында ыжгыру. *Хәлил Хәсәнович, арысланга әверелергә җыенган мәче кебек мырылдап, үзалдына ыжгырып алды.* Ф.Яхин

**Ыжгырып җибәрү** Кинәт ыжгыра башлау

**Ыжгырып куюу** Бер тапкыр ыжгыру, кыска гына ыжгырган тавыш чыгару. *Йокы булмәсе ишеген ябар алдыннан, «карт себер күкесе» усал итеп миңа карап алды да елан шикелле ыжгырып куйды.* Я.Шәфыйков

**Ыжгырып тору** Бертуктаусыз ыжгыру. *Авылын, җил ыжгырып торган сараен, төн чыкканчы, ул да сагынып өлгергән иде.* Н.Әхмәдиев

**ЫЖГЫРЫП** *рәв.* 1) Зур тизлек белән. *Чиксез-кырыйсыз киң дала, куе урманнар аша поезд, ыжгырып, алга бара.* С.Сабиров

2) Янаулы куркыныч кыяфәт, төс алып. *Акъялның ыжгырып үзе өстенә килүен күргәч, шүрләде, ахрысы, утардагы икенче бер юаш атны җигеп йөрүне кулайрак санады.* В.Имамов

3) *күч.* Кинәт, тыелгысыз, тоткарлыксыз. *Гади халыкка көн дә кирәкле әйберләргә бәяләр ел башында ыжгырып күтәрелде.* Татарстан яшьләре

4) *күч.* Ябырылып, һөҗүм итеп. *Ник шул карурман уртасындагы Каракүл тирәсенә ач бүреләр ыжгырып килми, агачларны ега-ега гарасат давылы үтеп китми, уналты яшьлек күңелгә мәхәббәт ялкыны кабынган икән, аны сүндерер әмәл юк.* А.Гыйләҗев

**Ы́Ж ИТҮ** *ф. к.* **ыжылдау** (*1 мәгъ.*). *Ыж-ыж итеп сызгырып, тәрәзә капкачларын шакылдата, морҗалардан кереп, озын иттереп сузып, моңлы, куркынычлы улый торган кышкы җилнең тавышына уянып киттем.* Г.Исхакый. *[Кыш бабай] – Ыж-ж... ыж-ж... итәрмен, Таулар аша үтәрмен, Елга-суларыгызны Шоп-шома боз итәрмен.* Р.Курамшин

**ЫЖЛАТУ** *ф. сөйл.* 1) *йөкл. юн. к.* **ыжлау**. *Әби, самавырын ыжлатып, кунакларны табынга чакырды*

2) *күч.* Нинди дә булса эшне әйбәт һәм тиз эшләү. *Егет эшкә бик уңган, нәрсәгә тотынса да ыжлата гына*

3) *күч.* Нәрсәне дә булса яхшы белү, оста башкару. – *Немецчәне син үзең дә каты ыжлатасың икән!* А.Гыйләҗев

**ЫЖЛА́У** *ф.* 1) Сызгыруга охшаш сузынкы тавыш чыгару (җил, мотор, самавыр һ.б. тур.). *Караңгы төндә караңгы кара урманның куркыныч каты шаулавы, ыжлавы бөтен тирә-якны дәһшәтле бизгәгендә калтыратты.* Г.Иделле

2) *күч. сөйл.* Ис китү, игътибар бирү, илтифат итү; пошыну, борчылу. *Сакчылар, Бачманның Кызыл Сырт өстендә корылган чатырына инде кичке караңгылык төшеп беткән чакта, чем кара калпакка төренгән тоткын сөйрәп кергәч, тархан әүвәл ыжлап та карамады.* В.Имамов. *«Я Ходаем, үзең сакла!» дип, бар белгән догаларын хәтерләргә тырышты. Ә юлдашы ыжлап та бирми, куа гына машинаны.* Д.Булатова

**ЫЖ-ЫЖ** *ияРт.* Өзлексез көчле җил тавышын яки берәр нәрсә кызу әйләнеп торганда чыккан тавышны белдерә. *Менә озак үтмәде: әллә кайдан капкара болыт килеп айны каплады, җил чыкты, манара ыж-ыж сызгыра башлады.* Г.Исхакый. – *Ыж-ыж, – дип ыжгырды җил һәм без сөялеп торган тәрәзәнең форточкасын каерып ачты.* Ф.Җамалетдинова

**ЫЖЫЛДАВЫК** *с.* Ыжылдаган тавыш чыгара торган, ыжылдауга охшаган. *Көй дә түгел ул, нииндидер ыжылдавык тавыш, иске курай кебек.* Г.Гыйльманов

**ЫЖЫЛДАТУ** *ф. сир.* 1) *йокл. юн.* к. **ыжылдау**. *Ул, өенә кергәч, иске примусын ыжылдатып кабызып җибәрде*

2) Иреннәрен кысып, теш арасыннан ыжылдаган тавыш чыгару. *[Насрый] Якшәмбе һәм башка эшсез көннәрдә, --- көн буе теш арасыннан ыжылдатып, әллә нинди, күңелгә кайгы сала торган көйләр тартып, --- казарма эчендә тәрәзәдән-тәрәзәгә туктап йөри.* Ш.Камал

3) *күч.* Берәр авыр эшне тиз генә кызу хәрәкәтләр белән эшләп ташлау

4) *күч.* Берәр кешене, ачуланып, яныннан куып җибәрү

**ЫЖЫЛДА́У** *ф.* 1) *к.* **ыжлау.** --- *бакчада өстәл өстендә әбисенең --- җиз самавыры, кечкенә бер юлыннан адашкан паровоз кебек, оялып кына ыжылдап, төтәп тора.* В.Ильясов. *Тышта кичләтеп купкан буранның ыжылдап улаганы, ябылмый калган тәрәзә капкачын йолыккалап, шак-шок бәргәләгәне ишетелә.* Д.Булатова

2) *күч. сөйл. к.* **ыжгыру** (*4 мәгъ.*). *Мондый пистолетттан чыпчыкны гына аталар, Исмәгыйль, ә минеке кабан дуңгызын да бәреп ега дип ыжылдады хуҗа, төкереген чәчеп.* З.Мәхмүди

**Ыжылдап алу** Бераз, аз гына ыжылдау

**Ыжылдап җибәрү** Кинәт ыжылдарга тотыну

**Ыжылдап кую** Кыска гына итеп, бер тапкыр ыжылдау. *Шаһгали мыскыллы елмаеп, ыжылдап куйды: – Ә мин аны яратам!* З.Мәхмүди

**Ыжылдап тору** Һәрвакыт, гел ыжылдау. *Кайтып керергә җып-җылы бүлмәм, ыжылдап торган примусым бар.* Г.Кутуй

**Ыжылдый башлау** Ыжылдарга керешү

**Ыжылдый бирү** Ыжылдавын дәвам итү

**ЫЖЫЛДАШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **ыжылдау**

2) *сөйл.* Ямьсез итеп кычкырышу, бер-берен уздырып талашу

**Ыжылдаша башлау** Ыжылдашырга тотыну

**Ыжылдаша бирү** Ыжылдашуын дәвам итү

**Ыжылдашып җибәрү** Кинәт ыжылдаша башлау

**Ыжылдашып тору** Һәрвакыт, гел ыжылдашу

**ЫЗАН** *и.* 1) Җир биләмәләрен, кишәрлекләрне аерып, алар арасындагы чикне белдереп торган тирән буразна яки чирәмле юл; межа. *Күрше белән ике арадагы ызанда тузганак нәни кояшны хәтерләткән сары чәчәк аткан.* Н.Әхмәдиев. *Мин, ять-яшь егет, яшел чыршылар янында басып калдым, ә ул ызан юлы буйлап сарылыкка чумган каеннар ягына атлады.* Р.Фәйзуллин

2) *диал.* Буразна. *Эре бөртекләр белән төрле төстәге күкәйләр дә тубалдан ызанга тәгәриләр.* А.Гыйләҗев. *Җәйнең тимерне дә эретеп агызырлык челләсендә башын ат башыдай эре, салкын суда чылатылган әрекмән яфрагы белән каплап алды да күмде дә күмде ул бәрәңге ызаннарын.* А.Хәлим

3) *күч.* Фикернең, сүзнең төп юнәлеше, сөреше, эз. *Кыскасы, шагыйрьнең фикере бер ызаннан гына акмый, ул төрле яссылыкка күчеп борчыла, төрле юл һәм ысулларны уйлап карый, даимән гамьдә.* Н.Хисамов. *Сөйләшү бөтенләй бүтән яктан, ул көтмәгән ызаннан башланды.* Р.Батулла

**ЫЗАНДАШ** *и.* **1.** 1) Ызаннары чиктәш җир кишәрлекләре булган кешеләр, ызан күршесе. *Яшелчә бакчасында кыярларга су сипкәндә дә, ызандашларына: «Шөкер, әйбәт киленгә тиендек», – дип сөйли.* Казан утлары

2) Күрше, янәшәдә торган, урнашкан әйбер, объект. *Хотня авылы Шәрәфиев яшәгән Карадуганга ызандаш кына диярлек.* Р.Зарипов. *Бу спектакльдә һәм башка кайберләрендә алтмышынчы еллардагы яңарышның кыюсыз сыйфатлары һәм узган дистә еллардагы сыйнфый каршылыклар рухы үзара ызандаш булып яши.* Р.Игламов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Ызаннары уртак булган. *Пай җирләрен генә түгел, ызандаш күршеләр арасында да хәтта гомер буе эшкәрткән бәрәңге бакчасын бүлә алмаучылар бар.* Безнең гәҗит

2) Янәшә торган, чиктәш булган. *Кукмара белән Саба халкы гомергомергә ут күрше, ызандаш районнар булып яшәдек.* Т.Нәҗмиев. *Алар шактый еллар буе ызандаш колхозларны бергә-бергә җитәкләгән председательләр сыманрак хәтердә кала.* М.Вәлиев

**ЫЗАНЛА́У** *ф.* 1) Ызан белән аеру, чикләрен билгеләү; *русчасы*: **межевать**. *Бары җирне ызанлап алып, Теркәүләр палатасында рәсмиләштергәч кенә, ул кешенең шәхси милке исәпләнә башлый һәм салым түләргә кирәк була.* Безнең гәҗит

2) Чикләрен аерып күрсәтү, чикләү, бүлү, бүлеп чыгу. *1924 елда Урта Азияне милли дәүләтләргә ызанлап бүлү казах җирләрен берләштерүгә китерә.* Т.Кәримов. *1711 елда, Екатерина II (Әби патша) җирләргә генераль ызанлау үткәргәндә, шәһәрнең иске исеме яңадан кайтарыла.* Милли-мәдәни мирасыбыз

**ЫЗАНЛЫ** *с.* Ызаны булган, ызан белән аерылган. *Чыннан да, ул вакытта печән җирләре ызанлы булып, аерым хуҗалык чоры булган.* Р.Зарипов

**ЫЗБА** *и. рус диал.* Өй, авыл өе. *Җиң сызганып, юан бүрәнәләрдән ызба салдылар.* З.Мурсиев

**ЫЗБАЧ** *и. рус иск.* 1) Совет чорында, 1920 елларда авылларда оештырылган культура-мәгариф үзәге; уку йорты (изба-читальня). *Дөрес, сез әле салкында эшлисез, урманда яшисез, берниндi тормыш уңайлыкларын күрмисез, мәдәният казанышларыннан мәхрүмсез, ләкин күп тә үтмәс нибары ике-өч елда биредә зур клуб, ашханә, мунча, кибетләр, мәктәп, балалар бакчасы, ызбач, контора булачак.* З.Мурсиев. *Дөрес, аңа кадәр клуб бинасында «ызбач» дип аталган бер бүлмәдә күпмедер китап була.* Якты юл

2) *сөйл.* Шул үзәкне оештырган, аңа җитәкчелек иткән кеше, уку йорты мөдире. *Аның исемен дә, фамилиясен дә белүче булмады, «ызбач» дип кенә йөртәләр иде.* М.Мәһдиев. *Сүзләрең*

*бик матур, ызбач Сөләйман шикелле сөйлисең.* Р.Вәлиев

**ЫЗБРУЙ** *и. рус* Ат җигү дирбияче, камыт-дирбия, камыт-эшлия. *Кайвакытта ат ызбруен рәтләп, машина көйләп, җир башында озак торыла.* М.Мәһдиев. *Ләкин җиз тәңкәләр белән бизәлгән каеш йөгән ызбруй арасында юк иде.* Р.Батулла

**ЫЗБРУЙЧЫ** *и.* Ызбруй әзерләү-булдыру, төзәтү, карау һ.б.ш. эшләр башкаручы

**ЫЗГАР** *и.* Үзәккә үтә торган зәһәр суык, көчле салкын җил. --- *көн озынлыгы сигез сәгатькә җиткәндә, искечә гыйнварның сигезләрендә, кышның ызгары – крещение суыклары кешене сикертә.* К.Насыйри

**ЫЗГЫТУ** *ф. диал.* 1) Куандыру, шатландыру. Бик эшләп ызгыта торган кеше түгел

2) Котырту, үртәү. Артистлар килеп халыкны ызгыта гына, билетлар җитми кала

3) сөйл. Яман итеп әрләү, пыр туздыру. *Бигрәк теле усал, ызгыта гына*

**ЫЗГЫШ** *и.* 1) Кычкырыш, талаш, җәнҗал, гауга. *Гел ыгы-зыгы, ызгыш туып тора иде безнең өйдә...* М.Маликова. *Әнисе тузынды, ярсыды, әтисе һәрвакыттагыча ызгыштан, талаштан качу ягын эзләде.* Г.Мирһади

2) *сөйл.* Ике фикер, төркем, сыйныф арасында кискен бәхәс, бәрелеш, көрәш. *Тәхет өчен ызгышта ил бөлә.* А.Хәлим. *Тәхеткә Олуг Мөхәммәднең утыруы Туктамыш хан һәм Идегәй әмир вафатыннан соң Җучи олысында башланган үзара ызгышларны туктатмый.* Б.Хәмидуллин

◊ **Ызгыш алмасы** *к.* **ызгыш ызаны**. *Әгәр моны ызгыш алмасына әйләндермисез икән, мин сезне азат итәм.* М.Кәбиров. **Ызгыш җимеше** *к.* **ызгыш ызаны**. *Саниянең әнисе, тормышта меңгә берсе дә табылмастай хатын булып, баласына «ызгыш җимеше» дип кенә карады.* Б.Камалов. **Ызгыш йомгагы тәгәрәтү** Ызгыштыру. *Мәскәүне «дер селкеткән» Мәрвия – Мария Николаевна исә һаман ызгыш йомгагын тәгәрәтте.* Н.Гыйматдинова. **Ызгыш ызаны** Якларның үзара ызгышын китереп чыгарган кеше, әйбер, хәл, вакыйга. *Монда Рабига гаепле, ул – ызгыш ызаны.* Н.Гыйматдинова

**ЫЗГЫ́Ш-БӘХӘС** *җый. и. к.* **ызгыш-талаш**. *Ызгыш-бәхәстә аның биографиясенең кайбер мөһим моментлары чагылып калган кебек.* М.Гайнетдин

**ЫЗГЫ́Ш-ГАУГА** *җый. и. к.* **ызгыш-талаш**. *Баласының сәламәтлеге хакына ул гаиләдәге ызгыш-гаугаларны урап үтәргә омтылды.* М.Кәбиров. *Менә шул хикәя ызгыш-гауга китереп чыгарды да инде.* Г.Гомәр

**ЫЗГЫШЛЫ** *с.* 1) Ызгыш-талаштан торган, җәнҗаллы; бәхәсле. *Ул, бикә тизрәк кайтса, яңадан шул көндәше белән ызгышлы тормышка китәргә ашкына иде.* Г.Ибраһимов. *Ызгышлы ил бәхетле булмый.* Р.Зәйдулла

2) Ызгышырга һәвәс, ызгышырга ярата торган. *Ирле хатын ызгышлы булса, яшәүдән күңел кайтыр.* Мәкаль

**ЫЗГЫ́Ш-ТАЛАШ** *җый. и.* Кычкырыш, талаш, җәнҗал, гауга; шау-шулы бәхәс. *Ул [Белобородов], милләтара ызгыш-талаш чыгармау өчен, күп тырышлык куя.* В.Имамов. *Гаиләдә ызгыш-талаш күбәйде, характерлары туры килмәде, ахрысы.* А.Хәмзин

**ЫЗГЫ́Ш-ТУЗГЫШ** *җый. и. сөйл. к.* **ызгыш-талаш**

**ЫЗГЫШТЫРУ** *ф.* 1) *йөк. юн. к.* **ызгышу**. *Байлык яраштыра, юклык ызгыштыра.* Мәкаль

2) Махсус рәвештә үзара мөнәсәбәтләрен, араларын бозу, талаштыру; дошманлаштыру. *Аңа шул гына кирәк – угланнарны аталары белән генә түгел, үзара да ызгыштыру.* М.Хәбибуллин. *Түшәмнән алынган хәбәрләр белән генә ызгыштырып булмый, арада чын гауга куптарырга, тимерне кызуында сугарга кирәк, ди.* Т.Әйди

**Ызгыштырып бетерү** Үзара ызгыштыру дәрәҗәсенә җиткерү

**Ызгыштырып тору** Һәрвакыт, гел ызгыштыру

**ЫЗГЫШУ** *ф.* 1) Кычкырышу, җәнҗал кубару, талашу, гауга чыгару. *Агач ботакларында, койма өсләрендә, начар хатыннар шикелле, ярты гомерен үзара әрепләшеп, ызгышып уздыручы чыпчык халкы чыркылдый.* Г.Бәширов. *Гаиләдә торымнан-торымга була торган ызгыш-талашларның сәбәбе кайчакта онытыла, чөнки ир-хатын еш кына бөтенләй сәбәпсез ызгышалар.* А.Гыйләҗев

2) Кискен бәхәсләшү, нәрсә өчен дә булса көрәшү, даулашу. *Хак арттыру турында хуҗалар белән ызгышу бара.* Ш.Камал. *Алар, шулай байтактан бирле үзара ызгышып, низаглашып яши торгач, бу бәхәсне рәсми төстә үзләре әле һаман буйсынган Урда ханы гына чишсә чишә алыр дип, Олуг Мөхәммәткә киләләр.* Р.Фәхретдинов

**Ызгыша башлау** Ызгышырга тотыну. *Үзем дә аптырашта калам, һич көтмәгәндә берәрсе белән ызгыша башлыйм, я төртмә сүз әйтәм.* А.Гыйләҗев

**Ызгыша тору** Озак вакытлар, бертуктаусыз ызгышу. *Үзара ызгыша торгач, татарлар ярык тагарак янында калачак.* Р.Батулла

**Ызгышып алу** Бераз ызгышу. *Кайвакыт шул сөйләүчеләр бер-берсе белән якага яка килеп, ызгышып алалар.* Г.Бәширов

**Ызгышып бетү** Тәмам, бик нык ызгышу, ызгышу дәрәҗәсенә җитү. *– Икмәк бир! – дип еладылар, талашып, ызгышып беттеләр.* Г.Ибраһимов

**Ызгышып йөрү** Төрле урында, һәрвакыт, гел ызгышу. *Сез, ике туган, ни эшләп ызгышып йөрисез, Зөләйха апай?* М.Фәйзи

**Ызгышып китү** Кинәт ызгышырга тотыну. *Колония булуда ызгышып китеп, империалистлар үзара сугыша башладылар.* В.Юныс

**Ызгышып тору** Һәрвакыт, гел ызгышу; әле, хәзерге вакытта, күз алдында ызгышу

**Ызгышып яту** *сөйл. к.* **ызгышып тору.** *Керсәләр, ул тегеут борчасы белән ызгышып ята иде.* А.Гыйләҗев

**ЫЗГЫШЧАН** *с.* Еш ызгыш-талаш, җәнҗал китереп чыгара торган. *Садыйкны, ызгышчан дип, Мәскәүгә, партиянең Үзәк Комитеты карамагына озатырга ясадылар.* Г.Ибраһимов

**ЫЗГЫШЧЫ** *и.* Ызгыш-талаш яратучы, һәр вак-төяк өчен дә ызгышырга гадәтләнгән кеше; еш җәнҗал кубаручы зат. *Криг белән Эмийга унар мең сестерция штраф салдылар, ызгышчылар шуны китереп түләгәч кенә, гашыйк сөядгәрне азат иттеләр.* Р.Сәгъди

**ЫЗМА** *и. диал.* Ыңгырчак бавы, аел. *Кайсыдыр, иярен калдырмакчы булып, атның ызмасын капшады.* Г.Бәширов

**Ы́З-ЫЗ** *иярт.* **1.** Җил тавышын белдерә. *[Кыш бабай] – Ызз-ызз итәрмен, Ап-ак карны тетәрмен. Очыртырмын туздырып, Битегезне кыздырып.* Р.Курамшин

**2.** *ы. мәгъ.* 1) Авырту, сызлау кинәт көчәйгәнне белдереп чыгарган тавыш

2) Кемне дә булса үчекләп, ирештереп әйтелә

**ЫЗЫЛДАТУ** *ф.* Сүздә [з] авазын үтә ачык һәм сузып әйтү. *Ул [Байбиков], үзенең «Матур кызга» диган шигырен сөйләгәндә, кыз диган сүзнең «з»*

*хәрефен бик озын итеп сузган хәлдә, яман ызылдатып әйтә.* Ш.Камал

**ЫЗЫЛДА́У** *ф.* 1) Авыртудан, сызлаудан ыз-ыз дигән тавыш чыгару. *– Кара аны, олы кеше дип тормамын, шушы көтү куган чыбык белән сыртыңны яра башласам, шундый ызылдарсың – чыгып киткәнеңне сизми дә калырсың.* Х.Җәмил

2) Һаваны ярып ыз сыман тавыш чыгару; выжлау, ыжылдау. *Бу хатны язганда гына, яннан иксез-чиксез пулялар ызылдап үтте.* Ватаным Татарстан

3) Ыз-ыз дип үртәп тору. *Ызз-ызз, тота алмый, тота алмый*

**ЫК** *иярт.* **1.** Укшыганда яки очкылык тотканда чыккан тавышны белдерә. *Күрше кызын очкылык тотты, ул, чикләвек ваткандай: – Ык та ык, – диде.* Н.Гыйматдинова

**2.** *ы. мәгъ.* Искәрмәстән әйтелгән сүздән яки нәрсә әйтергә белмәүдән югалып торуны, тотлыгып калуны белдерә. *Бу исемне ишетүгә: – Ы-ык! – дип куйды Шәүкәт. Алай да үзен тиз кулга алды.* А.Хәсәнов. *Әйтерсең тамагына кылчык кадалды: Фәгыйлә «ык» дигән аваз чыгарды да тынсыз калды.* А.Әхмәтгалиева

**Ы́К ИТҮ** *ф.* 1) Нык бәрелгәндә, җиргә бик каты килеп төшкәндә шундый тавыш чыгару. *Җиргә төшкәч ык итеп, Карап тора Нужа бабай.* Н.Исәнбәт

2) Аптыраудан сүз таба алмыйча туктап калу; җаваптан гаҗиз булу. *Мин ык итеп катып калдым да бер җавап та бирә алмадым.* Г.Рәхим. *– Шушы маңка малаймы? – дип, Әлбирт тәмәкесен кабыза-кабыза кыт-кыт көләргә тотынган иде, кинәт кенә ык итеп туктап калды, төшенде булса кирәк эшнең асылын.* З.Мифтахов

◊ **Ык та итмәү** Нык тору, кымшанмау, бирешмәү

**ЫККЫ** *ы. к.* **ыггы**. *Мондый матур малай күргәнем юк иде. Көләме, Мавия? Дү! Ыккы!* М.Фәйзи

**Ы́К-МЫК** *ы.* Нәрсә эшләргә белмичә аптырап, икеләнеп торганда аңлаешсыз мыгырдап куюны белдерә. *--- аларның сөйләшүенә «ык-мык» ымлыклары, «ул-бу» алмашлыклары килеп кысыла башлады.* С.Поварисов

◊ **Ык-мыкка калу** Нәрсә эшләргә яки нәрсә әйтергә белмичә аптырау, югалып калу, чарасызлык халәте кичерү. *Секретарь шулай дигәч, ык-мыкка калды Бадиков.* Ватаным Татарстан

**Ы́К-МЫК ИТҮ** *ф.* Төгәл җавап бирә алмау, аптырап калу, туры җаваптан качырга тырышып авыз эченнән нидер мыгырдау. *Дәресен әзерләмәгән шәкерт кебек, Шакирҗан да, ык-мык итеп, авыз эченнән ишетелер-ишетелмәс нидер мыгырдану белән җавап бирүдән котылырга ниятли.* С.Сабиров

**ЫК-МЫК КИЛҮ** *ф. к.* **ык-мык итү**. *Кыз минем ык-мык килүемне аңлады.* Г.Әпсәләмов

**ЫК-МЫКЛА́У** *ф. сөйл. к.* **ык-мык итү**. *Фәгыйлә урысча азрак сукаласа да, берни дә аңламаган сыман, ык-мыклап тизрәк үтеп китмәкче була.* С.Сабиров

**Ык-мыклап тору** Әле, хәзерге вакытта ык-мыклау. *Көзгә туй итәбез, дидем, ык-мыклап торсаң, урлыйм да апчыгам үзеңне.* А.Әхмәтгалиева

**ЫКТЫМАТ** *с. гар. диал.* **1.** 1) Җыйнак, артык зур булмаган, уртача зурлыктагы. *Ыктымат гәүдәле иренең разведкага барып, берүзе ике таза аттай фрицны тотып алып кайтканын таныш-белешләренә горурланып сөйли иде ул.* Казан утлары

2) Пөхтә, җайлы, ипле. *Абый күңеленә хуш килгән, бер мәсләктә булган, яратып аралашкан хезмәттәше, уңган-булган, ыктымат зат турында, «дөнья бәһасе кеше» дип әйтеп куя иде.* Татарстан яшьләре

**2.** *рәв. мәгъ.* Пөхтә, җыйнак итеп. *Бу безнең сөлге шикелле? Син генә шулай ыктымат чигәсең бит, әнкәй!* А.Гыйләҗев. *Өс-башын хәрбиләрчә ыктымат киенеп, киң каеш белән гимнастёрка билен артка бөрештереп кыскан.* Казан утлары

**3.** *и. мәгъ.* Эчке җыйнаклык, төгәллек, алдан кайгыртучанлык. *Безнең Әлфәритнең хуҗалык ягыннан бер дә ыктыматы юк инде.* А.Расих

**ЫКТЫМАТЛЫ** *с. диал.* Пөхтәлеге, җыйнаклыгы зур булган. *Коръән нәшер итү эшендә тәрҗемәчедән алып китап төпләүчегә кадәр һәркемнең пөхтә, ыктыматлы һәм, әлбәттә, әзерлекле булуы шарт.* А.Тимергалин

**ЫКТЫМАТЛЫЛЫК** *и. диал.* Пөхтәлек, җыйнаклык, төгәллек. *Койрыктагы вагонның ишекләре ике яктан да ачык, ахыргы станциягә ярты сәгатьлек кенә юл калганга, машинист ыктыматлылыгын җуйган иде, ахрысы.* А.Тимергалин

**ЫКТЫМАТСЫЗ** *с. диал.* **1.** Җыйнаксыз, шапшак. *Ыктыматсыз кеше*

**2.** *рәв. мәгъ.* Җыйнаксызланып, шапшак хәлдә. *Фрося үзенең шактый ук ыктыматсыз йөрүен сизми дә иде бугай.* Ш.Маннур

**ЫКЧЫМ** *с. гар. диал.* 1) Таман, җыйнак (кием тур.). *[Пашканың] Өстендә уңа төшкән ыкчым гимнастёрка.* Н.Исәнбәт

2) Артык зур булмаган, уртача зурлыктагы; җыйнак. *Русиянең иксез-чиксез киңлекләрендә ыкчым гына җирләрне биләп ятса да, аның [Башкортстанның] җилләр исеп очына чыкмас далалары, киек адашыр кара урманнары, биек-биек таулары, кызлар карашыдай серле күлләре, дулкыннарын ак пароходлар ярган елгалары, йөгерек чишмәләре – санап исәптән язарлык, уйлап хәйран калырлык хәзинәләре бар.* Кызыл таң

**ЫКЫ́-МЫКЫ** *ы.* **1.** *к.* **ык-мык**

**2.** *җый. и. мәгъ. сөйл.* Икеләнү, шикләнү, нәрсә эшләргә, әйтергә белмәү, аптырау, анык кына җавап бирмәү, туры җаваптан качарга тырышу халәте. *Шартлатып турысын әйт тә сал! Ниемә ул ыкы-мыкы!* Р.Батулла

**ЫКЫ́-МЫКЫ ИТҮ** *ф. к.* **ык-мык итү**. *--- башка студентлар күпчелек очракларда --- үзләренә атап сорау бирелә калганда, җавапка кучәсе урынга, ыкы-мыкы итеп, аптырашта калалар.* Ф.Яхин

**ЫКЫ́-МЫКЫ КИЛҮ** *ф. к.* **ык-мык итү**. *Ачуташ капкан кебек, йөзе җыерылды. Бер агарды, бер кызарды, ыкы-мыкы килде.* Ә.Хәсәнов. *Ыкы-мыкы килеп, Дәрвиш күп сөйләде, алдый торгач буталып һәм хәтта күз яшьләренә дә батып бетте.* В.Имамов

**ЫЛАК** *и. иск. диал.* Кәҗә бәтие. *Курада ылак туса, арык буенда ут тишелер.* Мәкаль. *[Кәҗәнең] Сөте агып торган болак, эче тулы ылак, Ите тамагыңа бап, тиресе аягыңа кап, мөгезе пычагыңа сап, эчәгесен аршынга тарт, скрипкәчегә сат.* Н.Исәнбәт

**ЫЛАШТЫРУ** *ф. лингв.* [о] авазын [ы] авазы белән алмаштырып сөйләү

**ЫЛҖЫРА́У** *ф. диал.* 1) Җебү; юешләнеп формасын югалту, җәелү. *Җылы су белән җебеп яхшы ук ылҗыраган киез итек салкын бозга шакырдап каткан.* Ф.Хөсни

2) *күч.* Куркып югалып калу, нишләргә белми аптырап тору; мәлҗерәү. *Ярар, болай ылҗырап утырып эш чыкмас.* В.Нуруллин

**ЫЛКЫН** *и. гар. иск. диал.* 1) *к.* **алкым**

2) Күн, киез итекнең тамагы; *русчасы:* **подъём**

◊ **Ылкын булганчы** *тупас* Бугазына тыгылганчы (ашау тур.). **Ылкыны килгәнче** *к.* **ылкын булганчы**

**ЫЛКЫ́НГАНЧЫ** *рәв. диал.* Күп итеп, туеп алдан калганчы, маемлаганчы. *Кайтып ылкынганчы ашыйм да, берәр жиләс җиргә ятып, тагын берәр сәгать черем итеп алам.* Казан утлары

**ЫЛКЫНУ** *ф. иск. диал.* 1) Күп итеп, туеп алдан калганчы ашау

2) Артыгын ашап авыраю, маемлау, авыр халәт кичерү

**ЫЛЫС** *и.* 1) Нарат, чыршы, артыш кебек агачларның энәсыман яфрагы. *Урман эченнән үткән чакта инде уяна башлаган бөре, ылыс һәм нарат сагызы исләре аңкый.* В.Нуруллин. *Урманның иң матур көне егерме бишенче майда булды – бу көнне урман яңа аткан чәчәкләр белән тулы иде, агачлар яфрак ярып бетергән, нарат-чыршылар ылыс төсләрен яңарткан иде.* М.Хуҗин

2) Шул агачның ботагы. *Баш очына аклы-каралы буй тасма бәйләгән. Тасманың алгы өстенә ылыс кыстырган. Артыш ботагы.* Г.Гыйльманов. *Кышын атна буена балалар чиратлашып фермага мал асларын кырырга, тирес түгәргә, урманга ылыс сындырырга йөрделәр.* Л.Ибраһим-Вәлиди

**ЫЛЫСЛЫ** *с.* 1) Энәсыман яфраклы, шундый яфраклары булган. *Тайгада вак куаклар юк чамасында, агачларның күпчелеге ылыслы агачлар.* А.Тимергалин

2) Шундый яфраклы агачлар үскән, шул агачлардан торган. *Ылыслы урманнар*

3) Ылыс экстракты салып әзерләнгән, ылыс исе килеп торган. *Җылы суга муеннан күмелеп кереп ятты да, рәхәтлектән кинәнеп, күзләрен йомды. Ылыслы сабын, мунчала да, чиста сөлге дә кул астында гына иде.* Т.Әйди

**ЫЛЫСЛЫЛАР** *и. күпл.* Үсемлекләр патшалыгының мәңгеяшел энәсыман яфраклы агач-куакларны берләштергән төркеме (чыршы, нарат, карагай, савыр, артыш һ.б.). *Нәкъ менә ылыслылар озак яшәүләре белән дә аерылып торалар: иң озын гомерлеләре 3–4,5 мең елга кадәр яши.* Биология

**ЫЛЫСЛЫ-ЯФРАКЛЫ** *с.* Ылыслы һәм яфраклы агачлар аралаш булган; катнаш. *Татарстанда күбесенчә ылыслы-яфраклы урманнар үсә*

**ЫМ** I и. 1) Нәрсәне дә булса сүзсез аңлату өчен кул, баш, күз белән ясала торган хәрәкәт; ишарә. *– Ым белән сөйләшеп, Хөрәсән шәһәрен алган хәким кеше булыр ул [Хөлдерифун], Ханиям. Каф тавы артына барып, ым телен өйрәнеп кайтучы.* Н.Исәнбәт. *Аны палатага озата кергән кызу врач арттан, аның күлмәк итәгеннән тартты, ым белән артсыз урындыкка утырырга кушты, иреннәрен чак кыймылдатып: «Саграк!» – дип пышылдады.* А.Гыйләҗев

2) Яшерен очрашуда бер-берсен тану өчен алдан билгеләп куелган сүз; алдан билгеләнгән шартлы эш-хәрәкәт. *[Хан:] Тыңла, Җирәнем, хәзер яныңа чит илдән бер хәким керер. Аның ымнарына ым белән җавап бирергә тиешсең. Яхшы уйла: отсаң – уңыш, оттырсаң – илебезгә сугыш.* Н.Исәнбәт. *Әледән-әле караңгыдан каравылчы-күзәтчеләр килеп чыкты. Алар да барысы да ым сорадылар.* Н.Фәттах. *«Түбә» килеп керүгә, килешелгән ым буенча, тегеләр дә булмәгә кереп бөялделәр.* Т.Галиуллин

◊ **Ым бирү** *к.* **ымлау**. *Латыйпов, Нәҗипкә тукталырга боерып, ике кулы, иңбашлары, теле, каш-керфекләре белән меңнәрчә ым биреп караса да, Нургалиевне тыяр, туктатыр көч юк иде.* А.Гыйләҗев. **Ым кагу** *к.* **ымлау**. *Шулчагында Илбарс хан, ым кагып, баш вәзирне чакырып китерде дә аның колагына нидер пышылдады.* А.Тимергалин. **Ым салу** *к.* **ымлау**. *[Зөләйха әби] Мөхәммәт картка башы белән ым салып, исәнләшеп, капкадан кереп китә.* Д.Салихов

**ЫМ** II *ы.* 1) Авыртудан ыңгырашкан тавышны белдерү өчен кулланыла

2) Сүз башларга икеләнеп, әйтәсе сүзен, җавабын уйлап торганда әйтелә. *Хәзрәт түгәрәк сакалын учлап елмая төште, беравык үзалдына ым-м дип торды.* Г.Бәширов

◊ **Ым да чыгармау** Тавыш-тынсыз калу, сүз дәшмәү; түзем, сабыр булу. *Ым да чыгармыйча киттем яныннан.* Ә.Баян

**ЫМЛА́У** *ф.* 1) Ым, ишарә белән ни дә булса белдерү, аңлату, нәрсәгә дә булса күрсәтү. *Барысы да таралып, тәхет ягыннан чыгып беткәч, кахан аңа кечкенә өстәл янына утырырга ымлады.* М.Хәбибуллин

2) Ым теле белән әйтү, аңлату. *Хисами чукракка, ымлап, атны җигәргә кушты.* Г.Минский

3) *күч.* Кемнең дә булса берәр сыйфатына, үткәндә булган нindidер эш-хәлгә киная ясау, төрттереп әйтү. *[Гөлшәһидә] Саматовның [сүзеннән] нindidер ямьсез бернәрсәгә ымлавын сизенде.* Г.Әпсәләмов. *[Бүлнискә] Барып җитү белән туганмын. Ниндидер әүлиялеккә ымлаган тамгалар да, зур өметләр вәгъдә иткән битлекфәләннәр дә булмаган. Гап-гади, «прастуй» крәстиян малае.* Аманулла

**Ымлап алу** Кыска гына ым ясау. *– Әнә безнең яшьләрне күрәсезме? – диде Яңгура, медицина турындагы әңгәмәне бүлеп, һәм теге яктан баручы Мансур белән Илһамиягә ымлап алды.* Г.Әпсәләмов. *Хәйдәр Бәдретдингә, партадан төшеп тор дип, баш кагып кына ымлап алды.* К.Кәримов

**Ымлап кую** Бер тапкыр кыска гына итеп ым ясау. *Хөснулла башы белән генә ымлап куйды: ярар, әйткәннәреңнән барысы да җиренә җиткерелер, янәсе.* Ш.Камал

**Ымлап тору** Һәрвакыт, гел ымлау

**ЫМЛЫК** *и. лингв.* **1.** Ачык бер мәгънәсе, номинатив функциясе булмаган, иң кыска юл белән хис-тойгыларны, эчке кичерешләрне, ихтыярны белдерә торган сүз (мәс., и-их, һәй һ.б.). *– Урыс кешесе белән сөйләшеп утыру өчен, күп сүз белү кирәкми, фикерле бер-ике ымлык җитә, – дигән Роберт Миңнуллин.* М.Галиев

**2.** *с. мәгъ.* Ымлык белән белдерелгән, ымлыклардан торган. *Ымлык сүз. Ымлык җөмләләр*

**ЫМСЫЗ** *рәв.* **1.** 1) Тавыш-тынсыз, сүзсез, сөйләшмәгән хәлдә. *Бер ымсыз барганга, аның күптән эче поша, сүз кузгатырга теле кычыта иде.* А.Вергазов

2) Хәрәкәтсез һәм өнсез рәвештә. *Без бераз вакытка икебез дә ымсыз калып тордык, Хәйрүш миңа әллә ничек ерактан карый кебек тоелды.* Казан утлары

**2.** *с. мәгъ.* Тавыш-тынсыз, сүзсез. *Анда һава гаҗәеп саф, ымсыз тынлык.* Б.Камалов. *«Элмә, әткәй!» диясе килде, тик әйтә алмады. Ул телсез иде, өнсез һәм ымсыз иде.* Г.Гыйльманов

**ЫМСЫН** *и. иск.* Бик нык ымсындырган, кызыктырган әйбер. *Ымсынга – ымсын ашы.* Мәкаль

◊ **Ымсын ашы** Ымсынган, кызыккан, ашап карарга теләгән ризык. *Билләһи, ымсынганга ымсын ашы инде менә!* Казан утлары. **Ымсын ризык** *к.* **ымсын ашы**. *Бу дөньяда бары шул бәхетле – Кадрен белгән йөзе аклыгын, Ымсын ризык алга килгән чакта Саклый белгән намус сафлыгын.* Ә.Хәсәнов

**ЫМСЫНДЫРГЫЧ** *с.* Үзенә тартып кызыктырып торган. *Ерактан, сукмак очындагы агачлар куелыгыннан*

*ымсындыргыч яктылык үрелеп карый башлагач кына, [Хәлим] туктап тын алды.* Г.Гыйльманов

**ЫМСЫНДЫРУ** *ф.* 1) Нәрсәсе беләндер кызыктырып, нәфесне кузгату, үзеңдә булдырырга яки тәмләп карарга теләк, омтылыш уяту, кызыктырып тору. --- *нәфис итеп туралган кара икмәк сыныклары да, күзәнәкләре белән ымсындырып, авыздан сулар китерә иде.* М.Маликова. *Уртадагы киштәдә, ымсындырып, яңа китаплар күз кыса иде.* Н.Гыйматдинова

2) Игътибарны җәлеп итеп үзенә тартып тору, нидер ышандыру, өметләндерү. *Алда ниндидер билгесезлек – серле, ымсындыра, үзенә тарта торган билгесезлек көтә иде...* А.Әхмәтгалиева. *«Эх, мин болай булсам иде, эх, мин тегеләй яшәсәм иде» дигән хыял канатлары аны әллә нинди биеклекләргә алып менеп, әллә ниләргә өметләндерә, ымсындыра иде.* Л.Ибраһим-Вәлиди

**Ымсындыра бару** Торган саен ныграк ымсындыру. *Шул дөнья, шул мохит безне үзенә һаман ныграк кызыктыра, тарта, ымсындыра барды...* М.Вәли-Барҗылы

**Ымсындыра башлау** Ымсындырырга тотыну. *Әмма, бара торгач, яккакка кереп китә торган юл-сукмаклар аны үзләренә чакырып ымсындыра башлады.* Г.Гыйльманов

**Ымсындыра төшү** Тагын да ныграк ымсындыру

**Ымсындырып бетерү** Бик нык ымсындыру; барысын да ымсындыру

**Ымсындырып җибәрү** Кинәт ымсындыра башлау. *Мостафа --- бакча ягына караш ташлады, шушы якты иртә, аклыкка төренеп, күперепкайнап утырган алмагачлар аның талымлы җанын кузгатып, ымсындырып җибәрде.* Ф.Сафин

**Ымсындырып кую** Кинәт ымсындыру. *Бүген дә Барый миңа иң якын дуска гына әйтелә торган бер сер әйтте. Дөресрәге, әйтеп бетермәде, күңелне генә ымсындырып куйды.* З.Хөснияр

**Ымсындырып тору** Һәрвакыт, гел ымсындыру. *Ә каен җилгә! Ул бөтенләй башка – урманга кергән һәр кешене куандырып, ымсындырып тора.* И.Салахов

**ЫМСЫНУ** *ф.* 1) Берәр нәрсәгә кызыгу, нәфесе кузгалу, үзенә алырга, татып карарга теләү. *Искәндәр, кучтәнәч көтеп, әтисенең бөктәрләренә ымсынып карады.* А.Гыйләҗев. *Теләртеләмәс кенә аккан балны ирләр, күзләрен дә алмыйча, ымсынып карап тордылар.* Н.Фәттах

2) Нәрсә дә булса эшләргә омтылу, тырышу. *Сүзгә катышып китәргә теләп, берничә тапкыр ымсынып, авыз ачарга итеп тә карадым, булмады...* Р.Мөхәммәдиев. *Сөннең элекке куәтен кайтарырга ымсынып карый каравын, әмма баштагы ялгышларын тагын кабатлый, йолаларны бозуын дәвам итә.* Л.Галитзуллина

3) Бик нык өмет итү, түземсезлек белән көтү. *Кабат очрашуга ымсынып яшәде.* Г.Гыйльманов. *Берсеннән-берсе матур кызлары, җегет булып җиткән уллары белән бәхетле Гыйсметдин, бәхетле Сәрбиҗиһан киләчәккә ымсынып яшәгәннәр, мәрхүмкәйләр.* Р.Батулла

**Ымсынып алу** Аз гына, кыска вакыт кына ымсыну. *Кыңгырау чәчәк касәләре ябылырга ымсынып алды.* Р.Фәйзуллин

**Ымсынып йөрү** Һәрвакыт, һәр җирдә ымсыну. *Сез күктәге йолдызларга ымсынып йөрерсез, ул, иелеп, җирдәгеләрен чүпләр.* Р.Вәлиев

**Ымсынып калу** Бик теләп тә ымсынган әйбере булмау. *Баланың күңеле ымсынып калачак, чөнки аның кызыксыну хисен берничек тә сүндереп булмый, ул телевизор гына түгел.* З.Хөснияр

**Ымсынып карау** Нидер эшләргә омтылып ымсыну. *Ул әүвәл, боландай җитез сикергәләп, агачны күтәрергә ымсынып карады, куәте җитмәде.* В.Имамов

**Ымсынып кую** Кинәт, аз гына, кыска вакыт эчендә ымсыну. *Бозауның киләчәктә сыер буласын күз алдына китереп, башта Равил үзе дә ымсынып куйды ул чакта.* В.Нуруллин

**Ымсынып тору** Һәрвакыт, гел ымсыну. *Шәһәрнең кибетләре, кинотеатрлары, музейлары – барысы да синең кесәңә карап ымсынып торалар.* М.Юныс

**ЫМСЫТУ** *ф. к.* **ымсындыру**. *Күңелне ымсыткан Өн генә бу бары – Әбиләр чуагы.* Р.Корбан

**Ымсытып тору** Һәрвакыт, гел ымсыту. *Әмма Кояш, хыял булып, Киек казны гел ымсытып торган.* Акчарлак

**Ы́М-ШЫМ** *и.* 1) Нинди дә булса тавыш, аваз, өн, тавыш-тын. *Һаман тынлык – ым-шым ишетелми.* М.Вәли-Барҗылы

2) Берәр төрле хәбәр, нәрсәгә дә булса ишарә, юрау, имеш-мимеш

**ЫНДЫР** *и.* 1) Урылган ашлыкны вакытлыча саклау, киптерү, сугу, җилгәрү өчен махсус әзерләнгән такыр урын, ачык яки өсте ябык корылма. *Сабанда сайрашмасаң, ындырда ыңгырашырсың.* Мәкаль. *Ул көнне без – Фәрзетдин, Миңлеәхмәт, мин – ындырда ашлык сугучылар янында булдык.* В.Нуруллин

2) *диал.* Кырдагы бәрәңге бакчасы (өй янындагы түгел). *Авыр булса да, бакчаны да, ындыр өлешен дә казып, бәрәңге утырттык ул елны.* Ә.Рәшит

◊ **Ындыр артлатып** Арт юллардан качып-посып, кешегә күренмәскә тырышып. *Таудан төшкәч, Әбүзәр, көрәкләре белән кеше күзенә чалынмас өчен, ындыр артлатып кайтты.* А.Тимергалин. *Менә ул тып-тын гына, төнлә генә, ындыр артлатып кына, шыпан-шыпан авылга кайтып керә.* А.Гыйләҗев. **Ындыр арты** 1) *диал.* Кыр бакчаның аргы башы тирәсендәге урын. *Безнең авылның урманы бик якын, ындыр артыннан ук башлана.* В.Нуруллин; 2) Гомумән йорткаралтылар артындагы урын. *Яшкенең лапаслары урынында, ындыр артларында әллә ничаклы тирес өелеп калды.* В.Имамов. **Ындыр артына да китмәс** 1) Курыкма, беркая да китмәс, югалмас; 2) Ашыкма, өлгерерсең әле (эшлисе эш турында). **Ындыр артындагы** 1) *к.* **ындыр артында гына**. *Ә үзебезнең ындыр артындагы әниләребез янына кайту турында исебезгә дә кереп карамый.* Р.Вәлиев; 2) Монда түгел, еракта, әллә кайда, кайдалыгы билгесез. **Ындыр артында гына** Ерак түгел, үз тирәбездә, якында гына. – *Дөньялар тынычланамы дип кенә торганда, тагын сугыш. Әллә кайда җир тишегендә түгел бит әле: ындыр артында гына сугышалар.* И.Гази. **Ындыр себеркесе** Ашлык көшеле өстендәге чүпләрне, ындыр табагын себерү өчен йомшаграк, нечкәрәк шәрә каен чыбыкларыннан бәйләнгән себерке. *[Равил абый] Кизү торганда, әз генә буш вакыты булса, кулына ындыр себеркесе ала.* Т.Нәҗмиев. **Ындыр табагы** Ашлык сугу өчен җирен су сибеп таптап, катырып, тигезләп ясалган такыр урын. *Ашлык сугу ярты кышта да бетмәде, болай булса, ындыр табагында эш язга хәтле сузылыр дип торабыз.* А.Гыйләҗев. *Быел ашлык котырып уңган иде, ындыр табагындагы көшелләр саны күзгә күренеп арта, үсә барды.* В.Имамов. **Ындыр төбе** Суккан ашлыкны җыеп алганнан соң җирдә калган һәм аерым җыела торган чүпле чәчем

**ЫНДЫРЧЫ** *и.* Ындыр эшендә эшләүче кеше. *Садыйков ындырчылар янында да булырга өлгергән.* С.Рәфыйков

**ЫҢГЫЛДА́У** *ф. сөйл.* Ыңгырашкан сыман тавыш чыгару. *Бәдрия, бусагадан атлап керүгә, лап итеп идәнгә утырды һәм тилемсә кеше төсле ыңгылдап елый башлады.* Казан утлары

**ЫҢГЫРАШ** *и.* Ыңгырашу, сыкрану авазы. *Хәзер вагон эчләрендә бары тик ыңгыраш, саташкан тавышлар гына ишетелә иде.* Г.Әпсәләмов

**ЫҢГЫРАШУ** *ф.* 1) Авыртудан яки кайгыдан сузынкы, әрнүле авазлар чыгару. *Ул [ат] зур күзләрен тутырып миңа карады, таныды, дымлы борын тишекләрен кыймылдатып куйды, нәзек тавыш белән ыңгырашып сәлам бирде.* А.Гыйләҗев. *Аңга килгәч, ыңгырашып аваз салды бугай, Әмирнең уң кулыннан күтәреп баручы шәүлә капылт туктап калды.* В.Имамов

2) *куч.* Шуңа охшаш тавышлар чыгару; шыгырдау (җансыз әйберләр тур.). *Кояш белән кара болытлар көрәшкән мәлдә, зәһәр җил-давыл кузгалып, агачлар бертуктаусыз ыңгырашып, гүләп тордылар.* Г.Гыйльманов. *Ирнең хәленә керергә теләгән сыман, аның артыннан, ыңгырашып, ишек ябылды.* А.Мансуров

3) *куч. сөйл.* Нәрсәдән дә булса бик нык зарлану, үкенү, зур канәгатьсезлек, ризасызлык белдереп сөйләү. *Сабанда сайрашмасаң, ындырда ыңгырашырсың.* Мәкаль. *Яшенә тыгылып елаган Нәфисә, башын калкыта төшеп, җан тавышы белән сөйли, юк, ачыргаланып-үрсәләнеп ыңгыраша иде.* Г.Гыйльманов

**Ыңгыраша башлау** Ыңгырашырга тотыну. *Хатын-кызны әйтмисең дә инде, ир арысланнарның да күбе, иртән бик баһадирланып керешсәләр дә, төшкә таба ыңгыраша башладылар.* Г.Ибраһимов

**Ыңгыраша төшү** Бераз ыңгырашу; тагын да ныграк ыңгырашу. – *Әйе, Аллаһ сабырлык бирде, – диде Һаҗәр, ыңгыраша төшеп.* Идел

**Ыңгырашып алу** Ара-тирә, сирәк кенә ыңгырашу. *Кайчакларны тирән сулап, җиңелчә генә ыңгырашып ала.* А.Хәсәнов

**Ыңгырашып җибәрү** Кинәт ыңгыраша башлау. *Ул таза, нык тешләрен көлгә әйләндерергә теләгәндәй шыгырдатып кысты, ыңгырашып җибәрде, аның ярым улау тавышына охшаган бу ыңгырашында чиксез үкенү, тирән, авыр сагыш бар иде.* А.Гыйләҗев

**Ыңгырашып кую** Бер тапкыр ыңгырашкан тавыш чыгару. *Шулай да, причал белән орынышкан мизгелдә, бөтен пароход тетрәнеп, шыгырдап, җан ияседәй ыңгырашып куя.* А.Тимергалин

**Ыңгырашып тору** Һаман, бертуктаусыз ыңгырашу. *Әкрен генә мыр-мыр ыңгырашып торсаң, ничектер авырту җиңеләйгән сыман.* Сөембикә

**Ыңгырашып чыгу** Нинди дә булса вакытның башыннан ахырына кадәр ыңгырашу. *Тәне таза-сау булса да --- төннәр буе ыңгырашып чыга башлады.* А.Әхмәтгалиева

**ЫҢГЫРДЫ́Й-ШЫҢГЫРДЫЙ** *рәв. гади с.* Теләмичә генә, ялындырып. *Ыңгырдый-шыңгырдый гына ризалашу*

**ЫҢГЫРЧАК** *и.* Атның сыртына куелып, өстеннән аркалык үткәрелә торган, өсте күн белән капланган киез мендәрчектән гыйбарәт җайланма, ат җигү дирбиясенең бер предметы. *Шуннан соң ул [озын мыеклы агай] атның ыңгырчак бауларын төзәтте, аркалыгын күтәрә төште, камыт чөелдереген сүтеп кысты.* М.Хәбибуллин

**ЫҢГЫ́Р-ШЫҢГЫР** *рәв. сөйл.* 1) Ыңгырашып, көч-хәл белән. *Олы кешенең шул ыңгыр-шыңгыр тирәсендә инде.* Сөембикә

2) куч. Авырлык белән, зур ризасызлык белдереп. *Хәзер ул [укытучыбыз], элгәреге кебек тырт-пырт кабынып, ыңгыр-шыңгыр зарланырга да тотынмый.* Э.Касыймов

**Ы́Ң-ШЫҢ** *җый. и. сөйл. к.* **ым-шым**. *Барды Йосыфым, ың-шың чыгармады, эшләгәнгә бер тиен түләмәсәләр дә, бастырып сүз әйтә алмады.* А.Гыйләҗев. *Кызыксынулар, ың-шыңнар, юраулар торган саен күбәйде.* М.Хәсәнов. *Өйдә ың-шың юк, әйтерсең лә мәет алып чыгып киткәннәр...* Д.Гыйсметдин

**Ы́Ң-ШЫҢСЫЗ** *рәв. сөйл.* 1) Тавыш-тынсыз, тыныч кына. *Әкълимә, почмакта ың-шыңсыз басып торучы Фердинандка ишарәләп: – Тыныч бул, бу – Фердинанд [диде].* З.Хәким

2) Ыгы-зыгысыз, ыгы-зыгы күтәрмичә. *Көннәр ың-шыңсыз гына үтә торды*

**ЫРА́-ЕРА** *рәв.* к. **ырып-ерып**. *Зәйтүнә, агач ябалдашларын ыра-ера, тау куышына җитте, үрелеп, кисәү агачын алды, чакма сугып ут кабызды һәм сак кына алга таба атлады.* М.Хәбибуллин

**ЫРАЙ** *и. гар. иск.* Уй, кәеф, күңел; мөнәсәбәт, фикер. *Чырае яман булса да, ырае яхшы.* Әйтем. *Чыраена карама, ыраена кара.* Әйтем

**ЫРАМ** *и. диал.* Нинди дә булса эшнең күзгә күренеп алга китеше, тиз эшләнүе; үрчем. *Бердәм эшнең ырамы зур*

**ЫРАМЛЫ** *с. диал.* **1.** Үрчемле, күзгә күренеп алга баручан; җитез. *Соры шинельле абый, итәкләреннән җилләр кузгатып, ырамлы адымнар белән аргы урамга җитеп бара иде.* Казан утлары

**2.** *рәв. мәгъ.* Тиз, җиңел, уңай. *Икәүләп [эшләгән] эш ырамлы бара икән шул.* З.Мурсиев

**ЫРА́У** *ф. диал.* Алга китү, үрчемле булу, күп эшләнү, тиз арту. *Уты сүнмәс, эше ырамас.* Әйтем. *Тула басам, тула басам, Тулам бер дә ырамый.* Җыр

**ЫРГАК** *и.* **1.** 1) Берәр нәрсәне эләктереп тарту яки әйбер элеп кую өчен очы ярым түгәрәк ясап кәкрәеп торган элгеч. – *Чамалагыз, егылып төшмәгез, – диде Алик, икесенә дә киң каеш бирде, ыргак беркетелгән чылбырны билләренә үзе кыстырды.* А.Гыйләҗев. *Таяк башындагы кечкенә факел белән андагы шәмнәрне кабызып чыккан да кандилне үз урынына кайтканчы ук ыргактан ычкындырган.* К.Шакиров

2) Шуңа охшаш һәрнәрсә. *Шул арада ыргак беләкле ике егет аны як-яктан килеп култыклап алалар.* Т.Галиуллин. *Каеннарның һәрбер ботагына Ыргак сыман сорау эленгән.* Казан утлары

**2.** *с. мәгъ.* 1) Очы яки үзе тулысынча кәкрәеп торган, ыргаксыман. *Төрледән-төрле бизәкләр кулланып носки, бияләйләр, ыргак энә белән мунчала, киезләр һәм башка хуҗалык кирәк-яраклары бәйли ул.* Безнең гәҗит. *Ыргак без*

2) Шундый формадагы детале булган, ыргаклы. *[Чүбекләре] Булган кешеләрнең чүбеген иске яулыкка төйнәтеп, ыргак бизмән белән үлчибез дә капчыкларга аударабыз. Ике гөрәнкәсенә өч тиен.* Казан утлары

**ЫРГАКЛАНДЫРУ** *ф.* Ыргак рәвешенә кертү, ыргак сыман итү

**ЫРГАКЛАНУ** *ф.* Ыргаксыман рәвеш алу, ыргак кебек бөгелү, кәкрәеп тору. *Борын төбендәге ике бөртек мыегы, ыргакланып, өскә бөгелгән.* А.Хәсәнов. *[Каракош] Томшыгының очы ыргакланып бөгелеп килгән.* Биология

**Ыргакланып калу** Нинди дә булса сәбәптән соң ыргаклану. *Сайларлык башка койрык булмаган, ана дуңгыз бик аптыраган, шул койрыкны тагып алган да кәкрәйтеп салган. Шул көннән алып барлык дуңгызларның да койрыклары ыргакланып калган.* А.Алиш

**Ыргакланып тору** Әле, хәзерге вакытта ыргакланган хәлдә булу. *[Кавын баш] Ыргакланып торган кара калын*

*бармаклары белән күз төпләрен сөртеп алды.* Казан утлары

**ЫРГАКЛА́У** *ф.* 1) Ыргак сыман итеп бөгү, кәкрәйтү

2) Ыргак белән эләктереп тарту, бәйләү. *Тегү машинасына ял юк, диван япмаларын да бизәп тегә, ыргаклап бәйләүгә дә вакыт таба.* Ютазы таңы

**ЫРГАКЛЫ** *с.* 1) Ыргагы булган, ыргак беркетелгән. *Болар озын баскычларны, ыргаклы арканнарны да алдан әзерләгәннәр.* В.Имамов. *Ат өстеннән ыргаклы бау ыргытып, ике тирмәне дә сөйрәтеп алып киттеләр.* Р.Сәгъди

2) Ыргак рәвешендә, ыргак итеп эшләнгән. *[Бу вакытта] Балыкны ыргаклы сөңгеләр белән тотканнар.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

**ЫРГУ** *ф. к.* **ыргылу**. *Миңнетдин, Җиде Авыз Мостафа, итәкләренә бала-чагалары сарылган Сәгыйдә, Тәүзихалар, өркегән сарык өере сыман таш-түмгәкләр аша ыргып, буза купкан җиргә ябырылдылар.* А.Хәлим. *Ул арада кызый йөгереп килеп җитте дә, шул килгән уңайга ыспай гына ыргып, мәһабәт гәүдәле Зәбирнең кочагына менеп тә кунаклады.* Г.Гыйльманов

**Ыргып алу** Кинәт кыска гына ыргым ясау. *Машина, бәйгедәге чабышкыдай, бер ыргып алды да килеп туктады.* Казан утлары

**Ыргып кую** Кинәт, бер тапкыр ыргу. *Кечкенә башлы, нәзек муенлы, нечкә сыйраклы, чынаяк күзле, без колаклы җен айгыры Уктай, йөрәгенең кагуына чыдый алмыйча, бер урында таптана, чыгымлап чигенә, авызлыгын кытыр-кытыр кимерә-кимерә, алга ыргып куя.* Р.Батулла

**Ыргып тору** Бертуктаусыз ыргу; әле, хәзерге вакытта ыргырга әзер булу, ашкынып тору. *Караңгыда шушы мәңгелек сазлыкның пычрагын ерып, дошманның ут ыргып торган тупларына каршы баручы меңнәрчә сугышчылар күз алдына килде.* Г.Бәширов. *Ярсып тора йөрәкләрем, Ыргып тора атларым.* Р.Миңнуллин

**ЫРГЫЛУ** *ф.* 1) Кискен хәрәкәт белән түбәнгә яки югарыга атылу, ташлану, сикерү. *Нинди уҗым басуы инде ул, ук булып ыргылып, күккә тургай күтәрелеп сайрамаса?* М.Мәһдиев. *Рәфис тагы бортка ыргылды, тик яңадан аны кире сөйрәп төшерделәр.* А.Вергазов

2) Зур тизлек белән берәр якка кискен хәрәкәт итә башлау, томырылу. *Шуны гына көтеп торган Ханәфи, арыслан җитезлеге белән ыргылып барып, арттан кочаклап алды Зәйтүнәне.* В.Нуруллин. *Кара айгыр җил капка аша урамга ыргылды.* А.Хәлим

3) Ургып, ташып, атылып чыгу (су, кан, ут, ялкын һ.б.ш.). *Буа ерылгандагы су ыргылган шикелле, балалар ишеккә ташландылар.* А.Алиш. *Баш сыярлык кына аралыктан сукрайтырлык булып көчле яктылык ыргыла.* К.Җәмит

4) Һөҗүм итәргә җыенып, җитез хәрәкәт ясау, кизәнү, ташлану. *Мин сүземне әйтеп бетерергә дә өлгермәдем, теге кечкенәсе, кадамакчы булып, пычагы белән миңа ыргылды.* В.Нуруллин

5) Кемгә дә булса ябырылып ташлану, өскә килү, өскә сикерү. *Бәйләнгән такта алачыгын өстерәп чабардай булып, аңа теге очтан эт ыргылды, тезгененең бөҗрасын капкага кадәр сузылган баудан зеңгелдәтеп килеп, амалап алам дигәндә генә, Григорий читкә сикереп өлгерде.* А.Хәлим. *Яраланган һәм кан исеннән котырган җанвардан да куркынычрак хәвеф иясе юк, ыргылып ябышса, күз ачып йомганчы боталап ташлаячак.* В.Имамов

6) *күч.* Нинди дә булса максатка, эшкә омтылу, теләгән, уен тормышка ашыру өчен ашкыну, атлыгу, җилкенү. *Кайберәүләр өчле-тугызлы тавыш белән профессиональ сәхнәгә ыргыла, юклы-барлы сәләте белән җырчы булырга маташа.* Р.Батулла. *Аның ише [зур төзелеш] эшләргә, гадәттә, татарлар күбрәк ыргыла, беләбез.* К.Җәмит

7) *күч.* Зур тизлек белән үтеп керү, таралу, җәелү. *Бу шартларда рухи өлкәдә сәнгатьчеләр өчен иҗат ирегә шактый киңәя, шуның белән бергә, модернизм алдында торган киртәләр алып ташлана, аның ярсулы агымы рәссамнар даирәсенә ыргылып керә ала.* К.Гыйззәтов. *Кызлар биегәндә, сәхнәдән нәфислек һәм затлылык, сафлык һәм тыйнаклык, наз бөркелеп тора, егетләр чыкса, залга ут чәчеп торган дәрт, ярсу, эчке энергия ыргыла.* Г.Шәйхи

**Ыргыла башлау** Ыргылырга тотыну. *Эт котырып өрергә тотынды, безнең якка ыргыла башлады.* И.Диндаров

**Ыргылып карау** Ыргылырга омтылу, омтылыш ясау. *Көчәнеп алга ыргылып карады, кузгала алмады, тәгәрмәчләр, сыек балчыкта сыпкы боламыгы болгатып, зыр-зыр әйләнделәр.* А.Гыйләҗев

**Ыргылып кую** Кинәт кискен ыргылу. *Уң як рульдәге резина тотканы бару уңаена таба чак кына бора төштеңме, мотоцикл шундук алга ыргылып куя.* В.Нуруллин

**Ыргылып тору** Һәрвакыт, гел ыргылу. *Бөтенебез бер булып, алгы көрәшләргә ыргылып торабыз.* А.Гыйләҗев

**ЫРГЫЛЫШ** *и.* 1) Кинәт зур тизлек белән кузгалып китү, алга ыргылу хәрәкәте; *русчасы*: **бросок**. *Авыртудан зәһәр ырылдап, бүре гәүдәсен читкә атты, Габделхәйнең кулыннан сәнәген бәреп төшерде, сәнәкне җирдән алган арада, бүре өченче ыргылыш ясады.* Г.Галиев. *[Хоккейчыларга мондый йөгерү күнегүләре] Аларның старт ыргылышларын тикшерү өчен кирәк.* Ватаным Татарстан

2) *күч.* Кыска вакыт эчендә ирешелгән уңыш, зур үсеш, тиз арада алга китеш; *русчасы*: **скачок**. *Җитди фәнни ыргылыш булды, тулаем алганда, борынгы шәһәрләрнең яшен билгеләүдәге методология һәм методика шактый баетылды.* С.Ибраһимова

3) *күч.* Бөтен көчне туплаган тырышлык, зур омтылыш, талпыныш

**ЫРГЫМ** *и.* 1) *спорт* Авыр атлетикада штанга күтәрүнең төп ысулларыннан берсе: җирдән кинәт күтәреп алып, баш өстенә туры кую; *русчасы*: **рывок**. *Кукмара районыннан Нурислам Башаров ыргым һәм герне кул белән этеп күтәрүдә өченче урын алды.* Ватаным Татарстан

2) *к.* **ыргылыш**. *Бүреләр якынайганнан-якыная, аралары күп дисәң бер ыргым калгандыр...* М.Әмирханов. *Казан аша халыкны таныта алуда гаять хикмәтле ыргым булды бу.* Р.Фәйзуллин. *Авылда сизәсең ипинең тир түгеп табылганын: тездән пычрак, юеш, салкын, кешеләр җитди, җилкенүле, юлларда машиналар үкерә, басуларда тракторлар гүелди – соңгы ыргым, быелгы урып җыюның соңгы көрәше бара.* Н.Гамбәр

**ЫРГЫТУ** *ф.* **1.** 1) Әйберне кулга алып, билгеле бер юнәлештә төбәп очыру, ату. *Өлкән килен Фәүзия келәт башыннан печән тырмаларын төшерде, зурлы, кечкенәле сәнәкләрне ыргытты.* Г.Ибраһимов. *Суалчанга черт иттереп бер төкерде дә кармакны, һавада сызгыртып, янә суга ыргытты.* В.Нуриев

2) Тәртип белән урнаштырмау, пөхтәләп куймау, ничек эләкте шулай атып бәрү. *Хәкимҗан абзый кәрәкерешкә кожаны белән сырмасын, бергә салып, мич арасына урындыкка ыргытты.* А.Гыйләҗев. *Алар, күлмәкыштаннарын ярга ыргытып, дулкыннарга ташландылар.* А.Хәлим

3) Кирәкмәс нәрсә буларак чүпкә ату, чыгарып ташлау. *Тәмәке төпчегенә төкергәләп сүндерде дә читкә ыргытты.* М.Хәсәнов. *Ул аларны [газит кисентеләрен], йомарлап, бер өемгә җыйды да кәрзингә ыргытты.* М.Кәбиров

4) Көрәшкәндә, сугышканда көндәшен кинәт күтәреп җиргә егу, кискен хәрәкәт белән күтәреп чөю. *Вафа, дошманының биленнән кысып алып, аны уңга таба каерды да шундук искәрмәстән чын бер көч белән икенче якка ыргытты.* М.Галәү. *Егет баш аркылы аны ыргытыр өчен артка егылганда, Рәфис аның өстендә булып чыкты.* А.Вергазов

5) *спорт* Көч белән этәреп, алга, ераклыкка очыру, ору, ташлау. *Тупны егерме өч метрга ыргыттым.* А.Гыйләҗев. *Ә бүген, һич уйламаганда, --- ат өстеннән сөңге ыргытуда да Александрга тиңнәр табылмады.* М.Әмирханов

6) *күч.* Нинди дә булса эшкә, эшчәнлеккә, хәрәкәткә юнәлтү, кычерү. *Торгытай тәүге уңышсызлык, тәүге корбаннар белән исәпләшеп тормады, һөҗүмгә яңа төмәнен ыргытты.* В.Имамов

7) *күч.* Кою, өзеп төшерү. *Алмагач та, тула һәм пешә башлагач, хуш исле алмаларын җиргә ыргытып, җир белән шаяра башлый.* Г.Кутуй. *Кояш җәйге челләдәгечә кыздыра, ә юл буе өрәңгеләре узучылар өстенә кырлы-сырлы алтынсу яфраклар ыргытып кала.* Казан утлары

8) *күч.* Ургытып чыгару, ату. *Тракторларың, бүрек-бүрек төтен ыргытып, озын буразналар буйлап йөрер.* Ә.Еники. *Чүмәлә чаклы пар болытлары ыргытып, паровоз кузгалды, вагон башмаклары шыгырдады.* В.Имамов

9) *күч.* Тар-мар итү, юкка чыгару; эш башыннан бәреп төшерү. *Ул боҗраны өзәргә тырышып һөҗүм иткән Манштейнны алып ыргыта.* З.Зәйнуллин

10) *күч. сөйл.* Туктап тормый юл уңаенда, кыска гына яки уйламыйча ни дә булса әйтү. *Ул --- кеше сүзенә кушылып китми, бары тик кирәкле урында, инде сүз әйтмәскә мөмкин булмаган җирдә генә бер-ике сүз ыргыта да тагын көйли башлый.* Р.Вәлиев. *Сәрвәр җилкә аша гына сүз ыргыта иде.* Н.Гыйматдинова

11) *күч. сөйл.* Кемгә дә булса яла ягып сүз чыгару, гөнаһсызга яман атын чыгару. *Атна-ун көн узмый, төшереп алган яшьтәшләр бер базарда сүз ыргыталар.* М.Мәһдиев

**2.** *ярд. ф. функ.* 1) Үзеннән алда килгән фигыль белән белдерелгән эш-хәлнең кинәт, интенсив башкарылуын белдерә. *Алар карны көрәп ыргыттылар.* А.Хәлим. *Үскән тигәнәк, әрем, сукыр кычыткан, алабута ише азау ярган чүп үләннәрен йолкып ыргытты.* Н.Әхмәдиев

2) Үзеннән алда килгән фигыль белән белдерелгән эш-хәлнең саксыз, артыграк, чамасызрак башкарылуын белдерә. *Бик җенләнсә, ботарлап ыргытырга да күп сорамас.* Н.Гыйматдинова

**Ыргыта бару** Һәрберсен, булган берсен ыргыту. *– Бәләкәй малайлар кипкән печәнне күбә-күбә итеп ат белән тарттырып алып килә тора, без озын агач сәнәкләр белән аны кибән өстенә ыргыта барабыз.* М.Вәли-Барҗылы

**Ыргыта башлау** Ыргытырга тотыну. *Без дә кулларыбыздагы тимертомырларны алар көймәсенә таба ыргыта башладык.* Ф.Әмирхан

**Ыргыта бирү** Ыргытуын һаман да дәвам итү

**Ыргыта төшү** Тагын да күбрәк, биегрәк яки ераграк ыргыту

**Ыргытып алу** Бераз, аз гына ыргыту. *Күптән түгел генә бер журналист җыр язучы шагыйрьләр бакчасына таш ыргытып алды.* Р.Вәлиев. *Сәгыйть берничә төртмә сүз дә ыргытып алды.* Ф.Сафин

**Ыргытып бетерү** Барысын да ыргыту. *– Мин төшеп, калган печәннәрне ыргытып бетерим, – диде Гайфулла.* Ф.Яруллин. *Андагы үзенең чикмәнен, Акмырзаның каеры тунын, түшәк һәм мендәр урынына түшәлгән арыш саламын – һәммәсен дә берәм-берәм куыш авызыннан тышка ыргытып бетерде.* Н.Яһудин

**Ыргытып җибәрү** Кинәт ыргыту. *Озак алыша торганнан соң, егет диюне күтәреп алып ыргытып җибәргән иде, дию килеп тезенә кадәр җиргә батты.* Әкият. *Ул башындагы такыясын алды да бик ераккa, биеккә ыргытып җибәрде.* Р.Рахман

**Ыргытып йөрү** Һәрвакыт, гел ыргыту. *Рушад, кайтып кергәндә, баскычта яткан почтаны күрде, кичәге, өченче көнге газеталарны, берни дә булмагандай, хат ташучы бөтенесен өя дә иртән кемнең ишек артына, кемнең баскычына ыргытып йөри.* Казан утлары

**Ыргытып карау** Ыргытырга омтылу, ыргытырга тырышу. *Сөләйман җайдакларны, диңгез дулкыннары кебек, катлы-катлы һөҗүмнәргә дә ыргытып карады, әйләнә буенча бертуктаусыз чаптырып, диварлар өстенә ук яңгыры да койды, ләкин юк кына бит, туп утлары төрекләрне манара һәм капкаларга якын җибәрмәде.* В.Имамов

**Ыргытып тору** Һаман, бертуктаусыз ыргыту; вакыт-вакыт ыргыту; әле, хәзерге вакытта ыргыту; әлегә, вакытлыча ыргыту. *Шушындый кискен бер минутта Җиһангирның балаларча ташлар ыргытып торуын күргән Саша Володаров чиксез ачуланды.* Г.Әпсәләмов. *Мәскәүгә ясак түләгән була, әмма Иван патша сизә – Күчем аның белән уен уйный, Мәскәүне ярсытмас өчен, аңа вакыт-вакыт калҗа ыргытып тора, ә үзе шул арада тәхетен ныгыта.* Ф.Бәйрәмова

**Ыргытып чыгу** Һәрберсен, барысын да бер-бер артлы ыргыту. *Кыш бик карлы булу сәбәпле, өй әйләнәсендә кар бик күп иде әле. Шуларны ыргытып чыкты Рафаэль.* Р.Мөхәммәдиев

**ЫРГЫТЫЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **ыргыту** (*1–7, 9, 12 мәгъ.*). *Кояш та, шуны сизгән сыман, үзенең якты нурларын, чәчү тубалыннан ыргытылган гәрәбә орлыклар кебек, җир өстенә сибә.* А.Алиш

2) *сир. к.* **ыргылу** (*2, 4 мәгъ.*). *[Закир] --- кечкенә соры күзләрен ерткычландырып, кулындагы дилбегәләре белән хатынга ыргытылды.* Г.Ибраһимов. *Аның тәрәзә аша урамга, Миңлебайның кочагына ыргытыласы, ә Миңлебайның исә, тәрәзәне рамы-ние белән куптарып ташлап, Мәрьямне үзенең көчле күкрәгенә кысасы килә иде...* Н.Яһудин

**ЫРГЫТЫШ** *и. спорт* Көч белән этәреп, алга, ераклыкка очырту, ору уены. *Ук атышта, сөңге ыргытышта, кылыч белән чабуда беркем аннан уздыралмый иде.* Н.Фәттах

**ЫРГЫТЫШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **ыргыту**. *Фатыйх абзый белән Зөфәр Хәлимович --- юл уртасында яткан ботакны алып ыргытышырга шофёр янына чыктылар.* Р.Сәгъди

2) Кара-каршы, бер-беренә ыргыту, атышу. *Кайвакыт җир өстендә зурзур валуннар – йомры ташлар очрый; аларның кайберләре яртылаш җиргә баткан, әйтерсең Алып батырлар таш ыргытышып уйнаганнар да җыймыйча калдырганнар.* Р.Кәрами

**ЫРЖАЮ** *ф.* 1) Һөҗүм итәчәген белдереп, казык тешләрен күрсәтеп авызын ачу (хайваннар тур.). *Ренат, ун бармагын да тырпайтып, көчекләргә үрелә башлаган иде, эт, ыржаеп, тагын ыргылды.* Казан утлары

2) *гади с.* Авызындагы бар тешләрен күрсәтеп, урынсызга ямьсез итеп көлү. *Бар да – шәфкатьсез, аяусыз, таш*

*йөрәкле бәндәләр, Чорнап алган да көләләр, ыржаеп ул гәүдәләр...* Һ.Такташ. *– Мин ул селәгәйләргә үзем аңлатырмын. – Маташма, әти. Әйтеп карадым – ыржаеп көләләр генә.* Р.Галиуллин

3) *күч.* Шыксыз, ямьсез булып күренү, куркыныч булып аерылып тору. *Яктылык тигез төшмәгәч, таш бурадагы керенте-чыгынтыларның кайсы, күләгәдә калып, күзгә дә чалынмый, кайсыберсе, уба тишегедәй ыржаеп, күңелгә шом сала иде.* А.Тимергалин

**Ыржаеп алу** Кыска вакыт арасында ыржаю. *– Йолкыш, ни йомыш? Ха-ха-ха! Нинди әйбәт рифмалаша икән бу сүзләр, – дип ыржаеп алды ул.* Ф.Яруллин

**Ыржаеп калу** Күпмедер вакыттан яки ниндидер сәбәптән соң ыржайган хәлгә килү. *Җил белән саламы каерылып очкан абзар түбәләре аждаһа теше шикелле ыржаеп калганнар.* М.Галәү

**Ыржаеп тору** Әле, хәзерге вакытта ыржайган хәлдә булу. *Ишектә олы амбар йозагы ыржаеп тора.* Т.Галиуллин

**Ыржаеп утыру** *сөйл. к.* **ыржаеп тору**. *Ташландык әвеннәр җимерек стеналары, тишек түбәләре белән ыржаеп утыра.* М.Галәү

**ЫРЖЫК** *и. диал.* **1.** 1) Ямьсез итеп көлүче кеше

2) *күч. к.* **алапа** (*3 мәгъ.*). *Бер атна үтмәгәндер, Мәрхәбәне сорап, ыржык хәтле бер кеше килде.* Г.Әпсәләмов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Ямьсез итеп ыржаеп көлә торган. *Алып Бәргән, ыржык авыз, сөяк башларны тыңлап тормастан, алга китте.* Р.Батулла

2) Зур гәүдәле, таза, нык. *Сәрвәрне кара син, гәүдәгә ничек зурайды, ыржык бер адәм булыр бу.* З.Мурсиев

◊ **Ыржыктай таза** Сәламәтлеге яхшы, нык; зур гәүдәле, көчле. *Хезмәткә (солдатка) киткәндә рәтләп аягына да баса алмаган Шакирҗаны хәзер ыржыктай таза егет иде инде.* К.Тинчурин

**ЫРИ** *ы.* Этне яки балалар бербересен үртәгәндә, котырткада әйтелә. *Егетләр, моның серкәсе су күтәрми икән, мәдрәсә тәртибенә өйрәтик, ыри, ыри, ыри...* Т.Гыйззәт

**ЫРКЫЛДА́У** *ф.* Ырылдау. *Туфраклы кар йомгагы эчендә кеше белән бүре ауный; кем кемне нишләткәнен аңлап булмый: бүре ыркылдаганы белән кешенең көчәнгәне генә ишетелә.* Р.Батулла

**ЫРЛАТУ** *ф.* Этне котырту, үртәү. *Ул менмәгән карга оясы, ул ырлатмаган эт калмый иде.* С.Рәфыйков. *Этне ырлатудан файда юк, тешләп алуы мөмкин.* Казан утлары

**ЫРЛА́У** *ф. к.* **ырылдау**. *Әмир «хезмәт көне» дип авызын әле ачкан гына иде, Дәү Сөләйман белән Фазылбәк икесе берьюлы ырлап ябыштылар.* В.Имамов. *Аңа карап торсаң, чынлап та хәзер бүре кебек ырлап ташланыр төсле тоела иде.* З.Кадыйрова

**Ырлап алу** Кыска гына ырлаган тавыш чыгару. *Егет, тавык ботын авызына капкан саен, эт булып ырлап алды.* Г.Исхакова

**Ырлап кую** Бер тапкыр ырлаган тавыш чыгару. *Саттар агайның көчеккә үрелүе булды, көчек өрмәде, артка да чигенмәде, тешләрен генә ыржайтып ырлап куйды.* З.Кадыйрова

**Ырлый башлау** Ырларга тотыну. *Бату хан ыбыр-чыбырга җавап сүзе кайтарып вакланмады. Үгәдәй белән Чагатайныкылар шикелле, арыслан-юлбарыслар ырлый башламады бит әле, алар өчен көч сакларга кирәк.* В.Имамов

**ЫРЛАШУ** *ф. к.* **ырылдашу**. *Ике бүлмәле иркен фатирның алгы ягында алагаем зур гәүдәле эт ята; үз тирәсенә елышып, чинашып, ырлашып уйнаган көчекләрен сак кына күзәтә иде.* Н.Акмал. *Сирайның тагын да ырлашырга нияте барлыгын сизеп, Рәфгать түзмәде, алагаемга берне китереп орды, чана үрәчәсенә барып төште малаең.* Казан утлары

**ЫРМА́У** I *и.* 1) Такта, борыс һ.б.ш. әйберләрне тыгызлап тоташтыру, җайлап урнаштыру өчен махсус ясалган уенты; җек. *[Бәрәңге бакчасының түр киртәсен яңарту] Озакка сузылды, баганалары черегән икән, яңа баганаларга ырмау алу кулны тотты.* М.Хуҗин. *Агач элементларны ныклап тоташтыру өчен, такта һәм борысларның бер читенә ырмау, ә икенчесенә сырт ясыйлар.* Төзү материаллары

2) *диал.* Кыса. *Лениза бу кешеләрдә тагын бер уртаклык барын күреп алды: хатын-кызлар һәммәсе бер үк төрле медальон таккан иде – нечкә чылбырга тагылган ырмау эчендә бишпочмаклы йолдыз.* М.Маликова

**ЫРМА́У** II *ф. к.* **ырмаулау**. *Ташны бүрәнә кебек ырмап булмый.* Г.Ахунов

**ЫРМАУЛА́У** *ф.* Берәр нәрсәгә ырмау ясау, ырмау алу. *Тоташтырасы урыннарны билгеләп, пычкы һәм өтерге белән тигез, пөхтә итеп ырмауладылар, балта түтәсе белән борысларны берберсенә кагып кертте.* Казан утлары

**ЫРМАУЛЫ** *с.* 1) Ырмавы булган, ырмау ясалган. *Ырмаулы такталардан җыелган тиңдәш өйләрне бер сызыкка тезеп, дүрт урам иткәннәр.* К.Кәримов

2) *диал.* Кысалы, кысасы булган. *– Бу собор Казанны җиңү хөрмәтенә салынган, – диде төркем алдында басып торган, аларга карап сөйләүче ырмаулы күзлек кигән хатын.* Р.Кәрами

**Ы́Р-МЫР** *иярт.* **1.** *к.* **ырр**

**2.** *рәв. мәгъ. күч. гади с.* Тыныша алмыйча, үзара килешмичә, талашып-ызгышып. *Ыр-мыр яшәү*

**Ы́Р-МЫР ИТҮ** ф. *к.* **ырылдау**

**Ы́Р-МЫР КИЛҮ** *ф. к.* **ырылдау**. *Бүре шунда белгән ырымнарын укып, ыр-мыр килеп, аның [төлкенең] койрыгын учлап, күзләрен йомган.* Н.Исәнбәт

**ЫРР** *иярт.* Этләрнең һәм кайбер ерткыч җәнлекләрнең ырылдаган тавышын белдерә. *Этләр, читтән карап, ыр-ырр дип, тешләргә кызыгып калдылар.* Г.Ибраһимов

**ЫРУ** *и.* 1) Кан кардәшлеге булган берничә буын; нәсел. *Ике арадагы низаг тәмам юкка чыксын, ике ыру алга таба гомер бакый дустанә вә имин хәят кына кылсын иде...* В.Имамов. *Гали ага Ильясовның нәсел-ыруы безнең авылга тоташканга күрә, ул Юлбат авылына эзен суытмады.* Р.Зарипов

2) *махс. к.* **ыруг** (*2 мәгъ.*). *Күп ашап корсакларын тутырганнан соң, күшәп, тыныч кына ятарга яраткан сыер ыруы, атлардан ераккарак китеп, үзләре өчен тынычрак урын эзли.* З.Зәйнуллин. *Үлән, орлык, бөҗәкләр булмагач, кошлар дөньясында ачлык башланган. Шуннан канатлылар ыруы кар төшмәгән җылы җирләр эзләп карарга булган.* З.Мурсиев

3) *сөйл. к.* **ыруг** (*1 мәгъ.*). *Бик борынгы дәверләрдә Каф таулары белән Урал тауларында алыплар ыруы яшәгән.* Г.Гыйльманов. *Гималайның сихри тауларыннан башлангыч алган йөгерек Амур елгасы буенда шәитләр ыруы яшәгән. Халык хәтеренә бу ыруның искиткеч кызы Нурисан кереп калган.* А.Нәҗми

◊ **Ыруга калдыру** Нәселгә, үрчемгә калдыру. *– Ишан хәзрәт, теге бозауны карадым, бик көр, симез, таза бозау. Ыруга калдырырга ярарлык.* К.Тинчурин. **Ырудан калу** Бала тудыру сәләтен җую. *– Бер ел узмасаң да, ырудан калдым микән әллә, дип хафаланып йөри башлыйсың бит ул! – диде әбием.* Э.Шәрифуллина

**ЫРУГ** *и.* 1) *тар.* Борынгы җәмгыятьнең төп социаль берәмлеге, кан

кардәшлеге нигезендә берләшкән һәм күмәк хезмәт белән яши торган кешеләр төркеме. *Запас туплау хатын-кызның ыруг эчендәге ролен бермә-бер күтәргән, шул нигездә матриархат – ыругта хатын-кызларның баш булуы, хөкем йөртүе туган дип тә уйлыйлар.* Р.Әхмәтьянов. *Мондый зур, иркен мәгарәдә халык та күп, йөзгә якын кеше, бөтен бер ыруг яши.* Р.Фәизов

2) *биол.* Систематикада: охшаш төрләрне берләштергән зур төркем, токым. *Бүре ыругы һәм Енотсыман эт ыругы, Төлке һәм Ак төлке ыруглары Этләр семьялыгына керә.* Биология. Үсемлекләр ыругы

3) *сир. к.* **ыру** (1 мәгъ.). *Җегетнең киткәндә әйткәне ике ыруг арасында канлы талаш булачагы белән куркыту иде.* Г.Ибраһимов

**ЫРУГДАШ** *и. тар.* Бер-берсенә карата: бер ыругдан булган кешеләр. *Аны [Гыйрфан мулланы Троицкида] ыругдаш, кавемдәш, кабиләдәшләренең дә ерак тарихы кызыксындырды.* Казан утлары

**ЫРУГЛЫК** *и.* Ыруг мөнәсәбәтләре. *Борынгы ыруглык җәмгыяте дәрәҗәсендә яшәгән ерак төньяк кабиләләре Идел Булгарына буйсынган булганнар.* И.Хуҗин. *Ыруглык җәмгыятендә барлыкка килгән мифологик карашлар, реаль яшәеш белән берләшеп, табигать дөньясы һәм кешелек дөньясы арасында гармония барлыкка китерә.* Г.Шәйхиева

**ЫРУДАШ** *и.* 1) *к.* **ыругдаш**. Күктәге *Тәңрегә, җирдәге ияләргә таянган, шуңа күрә үзенең көченә кирәгеннән артык ышанган Утташ кам ырудашларын ачыктан-ачык та, яшертен дә бигә каршы котырта башлады.* Н.Фәттах

2) Бер ырудан (*1, 2 мәгъ.*) булган, шул ыруга караган кешеләрнең яки җанлы организмнарның берсе. *Хайваннарның якын ырудаш төрләрен ыруг дип йөртелә торган аерым бер төркемгә берләштерәләр.* Биология

**ЫРУ́-КАРДӘШ** *җый. и. к.* **кардәш-ыру**. *Бәлки, кайчандыр аерылып киткән ыру-кардәшләребезнең бер тармагыдыр алар?* К.Җәмит

**ЫРУЛЫ** *с.* Ыруга (*3 мәгъ.*) берләшкән, бер уртак ыру булып яшәгән. *Ырулы ил – оялы каз.* Мәкаль. *Чая, эшкә батыр Данияне каенана, каенатасы да кызлары кебек кабул иттеләр, әнә шулай ул Зиннәтуллиннарның авылыбызда иң зур ырулы гаиләсенә килеп керде.* Яшел Үзән

**ЫРУ́-НӘСЕЛ** *җый. и. к.* **кардәш-ыру**. *Ыру-нәселеңнең дәвамы буларак тудырылган икәнсең, син үзең дә аның дәвамчысы булырга тиешсең.* К.Җәмит

**ЫРУ́-ТУГАН** *җый. и. к.* **кардәш-ыру**

**ЫРУЧЫЛЫК** *и. к.* **ыруглык**. *Борынгы ыручылык һәм күчмә патриархальлектән чыгып, болгар бабайлар да акрынлап утрак тормышка күчә, феодальлек тәртипләре җирләшә.* Н.Исәнбәт

**ЫРЫ́К-ШЫРЫК** *с. сөйл.* **1.** Җилкуар, җилбәзәк табигатьле (кеше тур.)

**2.** *и. мәгъ.* Шундый сыйфатларга ия кеше. *Юк, ул беркайчан ырык-шырыклар, ялкаулар рәтендә йөрмәде.* Р.Низами

◊ **Ырыкка да шырыкка** *гади с.* Юкка-барга, кирәкмәгәнгә. **Ырыкныкы шырыкка** 1) Җиңел юл белән генә, харамнан табылган малның тиз юкка чыгуы, әрәм-шәрәм булып бетүе турында. *Байдек, мескен, юклыкка чыдый алмыйча, баягы хатынның хәситәсен урлап кайткан иде, барысын да әрәм-шәрәм итеп бетерде: ырыкныкы шырыкка китте.* К.Насыйри; 2) Керемене карап чыгымы да китә бару турында; 3) Күп сүз сөйләү, гайбәт таратып җилбәзәкләнеп йөрү, бер кешенең гайбәтен икенче кешегә җиткерү турында. **Ырыкныкы ырыкка, шырыкныкы шырыкка** «Мал харамнан табылган булса, харамга, хәләлдән килсә, хәләлгә китәр» мәгънәсендә. **Ырык та шырык** Җитди кеше түгел, җитдилеге юк

**ЫРЫЛДАВЫК** *с. сөйл.* 1) Ерткычлар ырылдауга охшаш. *Ләкин ныклап йокыга китә алмады, урман чоңгылындагы бүре өне каршында ырылдавык тавыш ишетелде.* Г.Гыйльманов

2) *куч.* Төрле начар сүз, юк-бар сөйләргә гадәтләнгән, узган-барган кешене кычкырып үртәп кала торган

**ЫРЫЛДА́У** *ф.* 1) Бугаздан янаулы, түбән тонлы ырр дигән тавыш чыгару. *Рекс үрсәләнеп өрә, чиный, ырылдый.* З.Мәхмүди. *Тегенең [этнең] һаман ярсуы бетмәгән, тешләрен ыржайтып, бүреләр качкан якка карап ырылдый.* Д.Бүләков

2) *куч. гади с.* Усал җикеренү, кемнедер тиргәү, сүгү. *Үземә ялгыш кына кыек сүз әйтеп карасыннар, хәзер ырылдап ябышам.* А.Гыйләҗев. *Мурзаевның аларга иярергә теләвен күргәч, карсак кына бер малай, артка таба төкереп: – Якын килмә, сасык! – дип ырылдый.* А.Тимергалин

**Ырылдап алу** Аз һәм кыска гына ырылдау. *Сарбай сыртын кабартты, Зу-ур тешләрен ыржайтты. – Ыр-р-р! – дип ырылдап алды, Актүш боегып калды...* Р.Вәлиева. *Төлке ырылдап алды һәм теләр-теләмәс кенә урманга кереп шылды.* Т.Нәбиуллин

**Ырылдап җибәрү** Кинәт ырылдарга тотыну. *Арыслан, үрелеп карауга, кое төбендәге суда үз шәүләсен күреп ырылдап җибәргән.* Р.Вәлиев

**Ырылдап кую** Бер тапкыр ырылдау. *Арыслан ярсуын көчкә тыеп ырылдап куйган: – Кайда ул тел бистәсе?* Р.Вәлиев. *Аккүз кеше кебек ыңгырашып, ырылдап куйды.* Г.Гыйльманов

**Ырылдап тору** Әле, хәзерге вакытта ырылдау. *Кешеләр якынлашкач, бүре, тешләрен ыржайтып, бераз ырылдап торды да агачлар арасына кереп югалды.* Г.Әпсәләмов

**Ырылдый башлау** Ырылдарга тотыну. *[Маэмай] Ят кеше күрү белән, ямьсез ырылдый башлый.* А.Хәсәнов

**Ырылдый бирү** Ырылдавын һаман дәвам итү. *Картның сөйләшүеннән үзләренә нәрсә эшләргә кирәклекне аңлап алган ике зур ала эт, ырылдый биреп, капка төбендә торып калды.* З.Зәйнуллин

**ЫРЫЛДАШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **ырылдау**. *Юлбарыслар, ырылдашып, Яуга килеп кергәннәр. Килүгә үк, җәнлекләрнең Өстенә сикергәннәр.* Р.Вәлиева

2) *куч. гади с.* Талашу, кычкырышу. *Алар тагы ырылдашып, гаугалашып китә яздылар.* Х.Камалов

**Ырылдаша башлау** Ырылдашырга тотыну. *Моңарчы елмаешып кына торган дус, туган, күршеләр дә бер-берсенә теш ялтыратып, ырылдаша башлар.* Безнең гәҗит

**Ырылдашып тору** Әле, хәзерге вакытта ырылдашу. *Исхак зәһәр рәвештә кычкырып көлеп җибәрде: – Сүз әрәм итеп, синең белән ырылдашып торганчы...* С.Рәфыйков

**ЫРЫМ** *и.* 1) Төрле ышанулар нигезендә барлыкка килгән, магик йогынты ясау көченә ия булган, борынгыдан килгән гореф-гадәт, йола. *Ырым буенча, Арсланов ул әйберләрне – балдак һәм көмеш тәңкәләрне – биргән кешеләренә кайтарып тапшырырга тиеш.* М.Яһудин. *Элеккедән калган ырым буенча, ике бозауны өйгә бер ишектән кертергә ярамаган.* Р.Зарипов

2) Киләчәктә булачак вакыйгаларга ишарә итә торган юрама. *Шуның өстенә тагын бер начар билге, ырым килеп өстәлде. Юлга хәстәрләнеп беттек, чыгып утырабыз гына дигәндә, Мисхәт-Мишаның тормыш иптәше*

*Әлфия ханым күңелсез хәбәр, тамгалы галәмәт алып килде.* Т.Галиуллин

3) Кешеләргә, табигатькә йогынты ясый алырлык магик алымнар, чаралар; сихер, им-том. *Бер ырым белән кешеләрнең һушларын ала алганнар, кулаякларын буынсыз, хәлсез иткәннәр.* Ф.Урманче

4) Магик йогынты ясау өчен әзерләнгән дару, дәвалау чарасы. *Казан татарлары ислам дине кушкан гореф-гадәтләр һәм догалардан башка мәҗүсилектән калган ырым һәм им-томнар да ясыйлар.* К.Насыйри. *Бер карчыктан чүлмәк салдырды, бер хатыннан сылатты, күрше авылның керәшен хатыннан ырым ясатты.* Г.Исхакый

◊ **Ырымын белү** Серен, хәйләсен, җаен, тәртибен белү (берәр эшнең). *Абдрахман әкә! Син бер-бер ырымын беләсеңме шуның? Шамилнең исәнлеген өзеп кенә әйтә алмассыңмы?* Казан утлары

**ЫРЫ́М-ЕРЫМ** *и. сөйл.* Тигезсез, телгәләнеп, ермачланып беткән. *Бу балчык-тузан, ырым-ерым астында бихисап бәпкә үләннәре тамыры, хуш исле алма үләне орлыклары шыта алмый зар елап ята бит.* Казан утлары

**ЫРЫ́М ИТҮ** *ф. к.* **ырымлау**. *Гидай ырым итәр, ырымы кырын китәр.* Мәкаль

**ЫРЫМЛА́У** *ф.* 1) Төрле магик ырымнар (*2, 3 мәгъ.*) куллану, берәр максатка ирешү өчен, ырым белән эш итү. *Җир-су ырымлап яңгыр теләүләр дә тукталды.* К.Нәҗми. *[Борынгы кешеләр] Табигать көчләрен сүз белән ырымлап, ялварып буйсындырып була дип уйлаганнар.* Казан утлары

2) Ырым (*4 мәгъ.*) белән им-том итү, сихерләү. *Халык арасында төп тәңре Ирсанның абруе шактый үсә, аңа җәйләүләрдән төркем-төркем халык килә, төп тәңре аларның авыруларын дәвалый, ырымлый, өшкерә, тылсымлы сүзләр өйрәтә.* Казан утлары

**Ырымлап кую** Алдан ырымлау, ырымлаган хәлдә калдыру. *Әмма минем кыланышлардан кара көйгән Хабра Шабра калтамны ырымлап куйган.* Мәйдан

**Ырымлап тору** Һәрвакыт, гел ырымлау

**Ырымлый башлау** Ырымларга керешү. *Начтый түти ниндидер кипкән үлән-чәчәк бәйләмен суга манчып, минем өстә җилпеп, ырымлый башлады.* Туганайлар

**ЫРЫМЛЫ** *с.* Ырымы булган, ырым ясалган. *Чуваш хатынынnan китергән әллә нинди ырымлы икмәкне бисмиллясыз ашады...* Г.Исхакый

**ЫРЫМЧЫ** *и.* Борынгы ырымнарны белүче, аларны үтәүче кеше; күрәзәче. – *Син минем белән ырымчы телендә сөйләшмә, туп-туры гына әйт: хәбәр-хәтер бармы?* Н.Исәнбәт. *Ни әйтә ала Сәлим хан имче, албасты, ырымчы, сихерче, әфсен укып, әле ять-яшь кыз сурәтенә, әле төлкегә, кирәк икән тычканга әверелә алган Чәчкә Анага?* М.Хәбибуллин

**ЫРЫМЧЫЛ** *и.* Ырымнарга (*1–3 мәгъ.*) ышанучан кеше

**ЫРЫМЧЫЛЫК** *и.* Ырымчы шөгыле, ырым белән көн итү кәсебе. *Кешенең барлыкка килүенең башлангыч этапларында ырымчылык һәм шаманлык үсеше үзеннән-үзе дәвалау төшенчәсен барлыкка китергән.* Ислам

**ЫРЫ́М-ШЫРЫМ** *и. сөйл.* Һәртөрле ырымнар. *Шушы тойгы Миндиярның рухын какшатты, аның җан кыйблаларын изеп ташлады, ниһаять, бердәнбер көнне, ырым-шырым белән шөгыльләнүче Мәймүнә карчыкка алып килде.* Г.Гыйльманов

**ЫРЫ́П-ЕРЫП** *рәв.* Аралап, этәтөртә. *Саҗидә, керергә ярамый, магазинны төшкелеккә ябабыз, диюләренә карамастан, чыгып килүче халыкны ырып-ерып, эчкә үтте.* Ф.Яруллин

**Ы́Р-ЫР** *иярт.* Эт ырылдаган тавышны белдерә. *Аңгырайган башка ул ырыр булып ишетелде.* Н.Гыйматдинова

**Ы́Р-ЫР КИЛҮ** *ф. к.* **ырылдау**. *Газинур Чатанның ничектер бик сәер, хәтта беркадәр шатлык белән өргәнենә, кемнәрдер белән уйнарга тырышып ыр-ыр килгәненә уянып китте.* А.Хәсәнов. *Ул да сагынып зарыккан, сумкабызны куйганны көтәргә дә тәкате юк, шундук, ыр-ыр килеп, ишегалды чирәмендә тәгәри-тәгәри уйнарга тотына.* Ш.Маннапов

**ЫРЫС** *и. фар. иск.* Бәхет. *Агасы барның ырысы бар.* Мәкаль. *«Бәхетле бул, сөттәй татлы бул. Авызың белән аш килсен, Аягың белән ырыс килсен», дип, шундый-шундый сүзләрне әйтеп авызландыра.* Әстерхан татарлары

**ЫРЫСКАЛ** *и. фар. диал.* Бәхет. *Безгә диган ырыскал төшкән калган тырыстан.* Әйтем

**ЫС** *и.* Янып бетмәгән кисәүдән яки майлы матдә янганда, нәрсә дә булса өткәндә яки көйгәндә чыккан төтен. *Кире килгәндә – карлыган бакчасының зәңгәрсу очында хуш исле ыс, күңелгә якын бу аңкытып утырган мунча кырыеннан тыныч кына үтеп китә алмадым.* А.Хәлим. *Дала эченнән печән исе, чәчәк исе, кизәк исе, ыс исе килә.* Р.Батулла

◊ **Ыс җибәрү** Котырту, коткы салу, тәшвиш кузгату. *«Сәйлүн» кодалардан хатлар килә, Ыс җибәреп тора алар да. «Юк, мин әйтәм, мин бирешмим әле, Гел акылсыз түгел кодаң да».* Ш.Маннур

**ЫСКЫРТ** с. *диал.* Бик ачы, тозлы, кырку; ачы тәм кергән (май һәм майлы ризык тур.). *Малаемның мине иркәләүләреннән чыккан шатлык яшьләре битләремнән кайнар кургаш тамчыларыдай түбән тәгәриләр, кыек авызыма ыскырт ачы тоз булып тулалар, бөтен барлыгымны көйдерәләр.* Ф.Садриев

**ЫСЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **ыслау** I (*2–4 мәгъ.*). *Үзем яраткач, боларны да затлы нигъмәтләр белән сыйлыйм әле дип, шулчаклы тәмле, майлары тамып торган ысланган балык куям өстәлгә.* А.Хәсәнов

2) Ыс йогу, ыс исе сеңү. *Кашаповның йөзе дә соры, күз кабаклары да, соры чәче дә төтеннән ысланган кебек иде.* М.Галиев. *Давыт зәңгәрләнепкөмешләнеп торган даганы, бер чүпрәккә төреп, күмергә ысланып ялтыраган халатының ян кесәсенә төшереп җибәрде.* Г.Гыйльманов

3) *күч.* Искелектән чыга алмау, чынбарлыктан артка калу; карашлар искерү. *Кызны сатып алу? Бик кызык! Андый егет хәзер юк, кызый... Сезнең тормыш, картлар, ысланган, Калымы да шуңа охшаган.* Ә.Ерикәй

**Ысланып бетү** Тәмам, бик нык ыслану. – *Камерада да ысланып беттем инде, – дип төрттереп алды Хәбир.* Н.Акмал

**ЫСЛА́У** I *ф.* 1) Төтенләү, ис чыгару. *Мичтәге кисәүләр ыслый әле*

2) Ыс белән өртү, томалау, каплау. *Төтен-корым ыслаган тынчу шәһәр һавасына күнеккән үпкәләргә каен яфрагы белән җир җиләге исе кушылган татлы ис ят нәрсә иде.* Н.Гыйматдинова. *Гөрнәдирдәй егетләр, авыз читләренә сасы папирос кабып, дөньяны төтен белән ыслый иделәр.* Ф.Яхин

3) Төтенгә тотып ыс сеңдерү, ыста элеп киптерү, каклау. *Төлке агачка тавык суеп элгән дә, астына төтен салып, шуны ыслый, үзе агачка терәлеп утырган да китап укый икән.* Әкият. *Әсфәндияров куырган чучка балаларын, ул ыслаган балыкларны хәзер дә сагынып искә ала икән Сафуан Сабирович!* А.Гыйләҗев

4) *күч*. Берәр идея, хис, фикер белән сугару, шуңа төрү. *Унынчы елларда халык иҗаты әсәрләрен фальсификацияләп, милләтчелек сөреме белән ыслап, китап чыгаручылар да булды.* М.Мәһдиев

**Ыслап кую** Алдан ыслап әзер итү. *Бик зур кунакларына чучка ыслап куюларын да белә.* К.Тимбикова

**Ыслап тору** Әле, хәзерге вакытта ыслау. *Кам Аштабар, бер кулындагы төтен чыгарып, ыслап торган артышын селки-селки, Күзәмеш янына килеп, икенче кулындагы таягы белән астыртын гына аягына суга.* А.Гадел

**Ыслый башлау** Ысларга керешү. *Балыгын да үзебезнең авылда ыслый башладылар.* Ватаным Татарстан

**ЫСЛА́У** II *ф.* 1) Ысс иткән тавыш чыгару. *Мондый чакларда ата каз: «Артыгын кыланма, бик иркәләп, балаларны бозуың бар, тс-сс!» – дигәндәй, бер читтән карап, ыслап кисәтү ясый.* Ф.Яруллин

2) *күч.* Иреннәрен кысып, сүзен теш арасыннан чыгарып, усал итеп сөйләү. *Каты итеп, кайтарып сорамаслык итеп әйтте, теш арасыннан ыслап әйтте.* М.Хәбибуллин

**Ыслап алу** Кыска гына ыслау. *Рәхим тынын кысып ыслап алды: – Фәтхи атсыз торыр ди...* Ф.Сафин

**Ыслап кую** Бер тапкыр ыслаган тавыш чыгару. *Мәрьям иренең бу сүзләреннән ыслап куя.* Ф.Яруллин

**Ыслап тору** Әле, хәзерге вакытта ыслау. *Үзе әнә форточкадан миңа карап ыслап тора, нидер әйтеп выжлап тора.* Р.Фәйзуллин

**Ыслый башлау** Ысларга тотыну. *Әгәр елан сезне күреп, ыслый башласа, бу очракта кискен рәвештә хәрәкәт итмичә генә, кыргый хайван яныннан ераккарак китәргә кирәк.* Сабантуй

**ЫСЛАУЧЫ** *и.* Ыслап киптерүче, каклаучы кеше. *Тора-бара Интернеттан рецептлар табып, ыслаучылар белән киңәшләшеп, бу эшнең осталарына әйләнәләр.* Шәһри Казан

**ЫСЛЫ** *с.* 1) Ыс, төтен белән аралашкан, ыс сеңгән, ыс исе килеп торган. *[Очкычларның] Икесе дә ут төргәгенә әверелделәр дә, зәңгәр күктә ыслы кара эз калдырып, түбәнгә ыргылдылар.* Х.Госман. *Завод һәм фабрикаларның тәбәнәк кенә ыслы, корымлы корпуслары тезелеп киткән.* Казан утлары

2) Ысланган, какланган. *Ыслы чучка салолары төшләргә кереп йөдәтә.* Х.Мөдәррисова

**ЫСПАЙ** *с. фар.* **1.** 1) Пөхтә, җыйнак, һәрнәрсәсе үз урынында, зәвыклы итеп эшләнгән. *Җир йөзендә өч чабата бар: җәелгән мукшы чабатасы, тупас урыс чабатасы, ыспай татар чабатасы.* А.Хәлим. *Ыспай гына өй каршында Зөлмир тормозга басты, машина ишеген киң итеп ачып яңгыратып бакчада эшләп йөргән бер сеңелкәшкә эндәште.* З.Мурсиев

2) Килешле киенгән; купшы, көяз. *Бик тә ыспай кыяфәтле бер очучы белән күрше өстәлгә туры килделәр.* В.Имамов. *Ниһаять, бердән бер көнне теге ыспай егет белән якыннанрак танышырга җай чыкты.* Г.Гыйльманов

**2.** *рәв. мәгъ.* Килештереп, көязләнеп; җыйнак, пөхтә итеп. *Мөхәррир ханым гел генә пөхтә, ыспай киенә, ә бу яңа эшлекле костюмы бигрәк килешә иде үзенә.* Д.Булатова. *Мәктәп бакчасында малайларны ыспай киенгән, кулына папка тоткан урта яшьләрдәге ир-ат каршылады.* А.Гыймадиев

**3.** *и. мәгъ.* Көяз, купшы кеше. *Григорий Ялта – Симферополь юлын ике яктан да сырып алган милиция хезмәткәрләрен, штат киемендәге асаба ыспайларны күреп, аптырашта калды.* А.Хәлим

**ЫСПАЙЛАНУ** *ф.* Матур киенү, ясану, бизәнү, көязләнү. *Өс-баш та яхшы ук ыспайланган, урман һавасы да бик килешкән, ахрысы, яңаклары бодай кабартмасыдай күпереп, алсуланып тора.* Г.Әпсәләмов

**Ыспайлана бару** Торган саен күбрәк ыспайлану

**Ыспайлана төшү** Бераз ыспайлану; тагын да ныграк ыспайлану. *Мәсәлән, шәһәрләр төзү эшендә формаларның нечкәрә, пропорцияләрнең ыспайлана төшүе сизелә башлый.* К.Гыйззәтов

**Ыспайланып килү** Акрынлап, азазлап ыспайлану. *Шуңа күрә унсигез яшьтә генә дип тормады, хәтәр калкып, ыспайланып килгән Болгар каласына озатты аны [Ибраһимны] Мөхәммәт хан.* В.Имамов

**Ыспайланып китү** Кинәт яки соңгы вакытта ыспайлану. *Тузгыган бөдрәләрен рәткә китерде, шул ук тарагы белән сул колак турына каптырып куйды һәм сәхнәгә чыгып басарлык булып ыспайланып китте.* М.Маликова. *[Идегәй мирза] Җиңел, вак бөҗралы көбә күлмәктән булгангамы, ул бүген яшәреп, ыспайланып киткәндәй күренә.* Казан утлары

**Ыспайланып тору** Әле, хәзерге вакытта ыспайлану. *Кыз беренче тапкыр олы көзге каршында ыспайланып тора иде.* Казан утлары

**ЫСПАЙЛА́У** *ф.* 1) Ыспай итү, ыспай итеп бизәү, матурлау. *Алар [ирләр] күңелле гөрләшеп, мич арасында бит-кулларын юып, чәчләрен ыспайлап тарап, туп-туры табын тирәсенә сырыштылар.* А.Гыйләҗев

2) Пөхтә, җыйнак итү. *Мин аларны бик ыспайлап юка итеп төреп куйдым.* Г.Камал. *Посылка эчендәге әманәтләр, ыспайлап, ак кәгазьгә төрелгән иде, борынга тәмле ис килеп бәрелде.* Казан утлары

**Ыспайлап бетерү** Тулысынча, ахырга кадәр ыспайлау

**Ыспайлап кую** Алдан ук әзерләп ыспайлау

**ЫСПАЙЛЫК** *и.* Ыспай булу сыйфаты; көязлек, купшылык. *Ә ыспайлык ягына килгәндә, безнең Ану дөньядагы барлык атларның да иң матуры, су сөлеге күк нечкәсе, терекөмештәй җитезе һәм бик тә акыллысы.* Г.Госман. *Гаҗәп, ул аның --- каеш белән биленнән буган күлмәк итәкләрен тарткалап төзәтенүен дә, киеменең тәненә сыланып, ыспайлык өстәп торуын да күздән ычкындырмаган булып чыкты.* Т.Әйди

**ЫСПАС** *и. рус сөйл.* Христиан дине буенча көзен үткәрелә торган өч бәйрәмнең берсе. *Җитсә икенче Ыспас, Бияләй ал кулыңа запас. Өченче Ыспас – Кыяр тозла кышка запас.* К.Насыйри. *Өч ыспас – беренче, икенче, өченче ыспасларның тәртибе кирегә – өченче ыспас хронологик җәһәттән беренче.* Р.Әхмәтьянов

◊ **Ыспас яңгыры** Җилсез ява торган көзге вак яңгыр

**ЫСС** *иярт.* **1.** 1) Җил тавышын белдерә. *Чү, ысс, җилме, Кем ышкына, мышнап ишеккә.* Х.Туфан

2) Каз, еланның һөҗүм иткәндә яки куркыныч янаган вакытта кисәтеп чыгарган ысылдау тавышын белдерә

**2.** *ы. мәгъ.* 1) Башкорт биюен башкарганда, ритмга туры китереп әйтелә. *Шуннан соң, киемнәрен алыштырмыйча гына, егете бөеренә таянып, кызы иңбашын уйнаткалап һәм бармак шартлаткалап, икесе дә ысс-ыс дигән сәер бер тавыш чыгарып, башкортча биеп күрсәттеләр.* Ә.Еники

2) *к.* **ыз-ыз**

3) Тынычлануны, тавышланмауны сораганда әйтелә

◊ **Ысс булу** Үзсүзләнеп үзенчә эшләп хур булу, үзен аклап сүз әйтерлеге калмау

**ЫСС-ЫСС** *иярт. к.* **ысс**. *Ягъни мәсәлән, ата каз турында сүз чыкса, нәрсә диярбез? – Ысс-ысс, – диярбез.* Ф.Яруллин

**ЫСУЛ** *и. гар.* 1) Алым, юл; метод. *Үз ачышларыңны син шул ансат ысул нигезендә, әмма барыбер күп тырышлыклар куеп ясарсың, балам.* А.Тимергалин. *Румия, бу әйберләр бары да агалтыннан ясалган, махсус ысул белән.* В.Ильясов

2) Эшне башкару тәртибе, җае, әмәле. *Һәр эштә осталык, ысул, аз көч куеп, олы нәтиҗәгә ирешергә омтылу бар – бу да хәйлә!* М.Мирза

3) *иск. к.* **стиль** I (1 мәгъ.). *Чит мохиттә, җирле культура тәэсирендә, ысул үзгәрә. Ренессанс чорының мәшһүр архитекторы Франческо Лапареллиның Валлеттадагы сарайларында гарәпләр кулы сизелә.* М.Юныс

4) Үрнәк, зәвык; мода. *Аның әнисе, илленең аргы ягына атласа да, киемнәрен яшьләрчә ысул белән генә кия.* В.Имамов

◊ **Ысул дәфтәре** *иск.* Бухгалтерия. *Үзенең ысул дәфтәре белүе берлән, бухгалтер дип, бер галантерейный магазинга конторга кергә алды.* Г.Исхакый. **Ысулы җәдит** *иск.* Грамотага өйрәтүдә аваз методы, XX йөз башында яңача укыту-тәрбия методы. *Карагруһ кадимчеләрнең күпчелеге Бубиларны укытуда яңа метод – ысулы җәдит кертүдә гаепли.* М.Мәһдиев. **Ысулы җәдитче** *иск.* 1) Ысулы җәдит тарафдары; 2) Җәдитчелек тарафдары. *Ысулы җәдитчеләр тагын әле мәдрәсәләргә төрле дөньяви фәннәр кертkәннәр.* М.Мәһдиев. **Ысулы кадим** *иск.* Грамотага өйрәтүдә иҗек методы, искечә укыту-тәрбия методы. *«Рисаләи Газизә», – дип яза авторлар [Г.Рәхим, Г.Газиз], – безнең татарның бик яратыб укый торган китабларындан берсе; ысулы кадим мәктәпләрендә дәреслек итеб тә кулланылган.* Х.Миңнегулов. **Ысулы кадимче** *иск.* 1) Ысулы кадим тарафдары; 2) Кадимчелек тарафдары. *Хөласан мин [Әхмәтфәез] сезгә шуны әйтергә тиешлемен ки, минем мәсләкдәшләрем – ысулы кадимчеләр – Коръән, шәригать, патша вә хөкүмәт ягында торалар.* М.Мәһдиев

**ЫСЫЛДАВЫК** *с.* Ысылдый торган. *Ул ысылдавык тавыш белән: – Кешегә күпме аңлатырга мөмкин соң? – дип, сорауга каршы сорау белән җавап бирде.* Ф.Җамалетдинова

**ЫСЫЛДА́У** *ф.* 1) Ысс иткән тавыш чыгару (каз, елан тур.). *Бүрекле ата каз егетләрчә гаярь басып, Мифтахетдингә каршы ук китә һәм озын, юан чыбыркы муенын сузып яман ысылдый.* А.Гыйләҗев. *Каракош җирдә ята, әмма исән, бер канаты белән җилпенә, яман итеп ысылдый.* М.Хәбибуллин

2) Тынычланырга, ярамаган эштән тыелырга яки шым булырга кушып, нәрсәгә дә булса ишарәләп, ысс дигән тавыш бирү. *Әгәр аланда ярамаган эш кылучы булса, алар миңа ысылдап сигнал җибәрәләр.* Көмеш кыңгырау

3) Башкорт биюен биегәндә, ритмга туры китереп, ыс-ыс дигән тавыш чыгару. *Биегән чагында ысс-сс, ысс-сс, дип ысылдавы миңа бигрәк тә ошый һәм Зәлифә әби миңа кара-сары-яшел төстәге бик тә матур, әкияти елан булып тоела.* Казан утлары

4) *куч. сөйл.* Иреннәрне кысып, теш арасыннан гына усал итеп сөйләү, нәрсә дә булса әйтү. *Башын күтәреп, Мәхмәткә карап тора, теш арасыннан ысылдый: – Ә менә син дошман!* З.Хәким. *Ул арада юлбасарларның берсе пычагын Акмулланың бугазына ныграк тери төшә: – Кайда синең байлыгың, сәсән?! – дип ысылдый ди.* Р.Батулла

5) *куч. сөйл.* Сөйләшкәндә, чыжылдаулы авазларны сызгырулы авазларга алыштырып сөйләү (мәс., Дөбьяз сөйләшендә: *пычак – пысак, әчкеч – әскес*)

**Ысылдап алу** *к.* **ысылдап кую**. *Тау иясе, исәнләшкән сыман башын калкытып, җиңелчә ысылдап алды һәм киң ботаклы юан имәнгә уралды да көтә башлады.* Н.Фәттах

**Ысылдап җибәрү** Кинәт ысылдарга тотыну. *Менә ул [Мәнти карчык] сикереп-сикереп бии, ысылдап җибәрә.* Р.Сәгъди

**Ысылдап йөрү** Һаман, һәрвакыт, озак вакыт ысылдау. *Ислам гына һаман, тешләк бабай сыман, гел ысылдап йөрде. В.Имамов*

**Ысылдап кую** Кинәт, кыска гына ысылдаган тавыш чыгару. *Шул вакыт теге карчык ике кулын да алга – Хәлимгә таба сузып җибәрде, үзе йөзен чытып, күзләрен кысып, ысылдап куйды.* Г.Гыйльманов

**Ысылдап тору** Һәрвакыт, гел ысылдау. *Гөнҗәлә бүрекле, эре гәүдәле күгәрчен гел кукраеп, йоннарын кабартып, ысылдап тора.* Казан утлары

**Ысылдый башлау** Ысылдарга тотыну. *Ул [әнкә каз] Алихан якынлашуга ысылдый башлый.* З.Хөснияр

**Ысылдый бирү** Ысылдавын һаман дәвам итү. *Әйдә, ысылдый бирсен лә! Барыбер курыкмыйлар ич аннан.* Р.Вәлиев

**ЫСЫЛДАШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **ысылдау**. *Аларның янәшәсендә генә, муеннарын сузып, ике ата каз ысылдаша.* Р.Вәлиев

2) *куч.* Иреннәрен кысып, теш арасыннан гына усал итеп сөйләү. *Юк, кычкырышып түгел, татарлар, гомумән, кеше алдында кычкырышмый бугай, ысылдашып кына талашалар болар.* Шәһри Казан

**Ысылдашып алу** Кыска гына ысылдашу. *Бикәләр бәпкәләренә куркыныч янаган ана каз шикелле ысылдашып алдылар.* Казан утлары

**ЫТЫРГА́У** *ф. диал.* 1) Җирәнү, чиркану. *Менә шуннан соң хәләл язуы сугылган ит әйберләрен дә ытыргап кына сатып алам.* Безнең гәҗит

2) Җәлләү, кызгану; әрнү, борчылу. *Ытыргаган баланың бәхете булмас.* Мәкаль

**Ытыргап кую** Кинәт, кыска вакыт арасында ытыргау. *Әхмәтсафаның күңеле ытыргап куйды, әйтерсең яланаягы белән салкын бакага китереп басты.* И.Гази

**ЫХ** *ы.* 1) Авыр сулыш алуны белдерә. *Галинур ярсудан буылгандай кыланып сүз башлады: – Мин... ых... сеңлемне күрергә килгән идем...* Ф.Садриев

2) Көлгән тавышны белдерә. *Рөстәм дә, тамак төбеннән ых-ых дигән авазлар чыгарып, тыела алмыйча көлә.* Көмеш кыңгырау

3) Йөткергән тавышны белдерә. *Ул, кесәсеннән кулъяулыгы алып, маңгаен, битен сөрткәләп, тагы ых-ых йөткергәләп куя.* Казан утлары

4) Ыңгырашкан тавышны белдерә. *Ы-ых... Атасының ыңгырашуын ишетеп, Дамир йөгереп керде.* И.Сиражи

◊ **Ых дигәнче (дип әйткәнче)** Бик кыска вакыт арасында, бик тиз генә. *Әмма Шакирҗан бер тында, ых дип әйткәнче, юан каен бүрәнәне кып итеп кенә кисеп ташламакчы.* С.Поварисов. *Төнге кунаклар аны ых дигәнче бәйләп ыргыттылар.* З.Мәхмүди

**Ы́Х ИТҮ** *ф. к.* **ыхылдау**. *Башта аның тыны капланды, ул сулыш алалмыйча ыһ-ых итеп торды, сулышы рәтләнгәч, тирән тын алып, суга чумды.* Р.Батулла

◊ **Ых иткән** Бернинди дә. *Ә бала йоклый иде, аның ых иткән тавышы да ишетелмәде.* Р.Габделхакова. **Ых та**

**итми** *к.* **ыһ та итми**. *Беләсезме, туганкаем, алдымда япь-яшь кыз, фельдшерлыкка укырга килгән, мин аңа табибларга бирелә торган сораулар бирәм, ә ул, ых та итми, шундук җавап кайтара.* З.Мурсиев

**ЫХЫЛДА́У** *ф.* 1) Авыр итеп еш-еш сулау. *Әхәт бу юлы да --- башкаларның ыхылдап авыр такта бәйләмнәрен күтәреп ташыганнарын карап утырырга җыенган иде.* К.Булатова

2) Сулкылдау, үксү. *Анысы узгач, тагын бер дулый-дулый, ыхылдап-ыхылдап, тирә-юньдәге гаепсез чәчәкләрне умыра-умыра, ямьсез итеп елады.* Казан утлары

3) Ыңгырашу. *Хатын: – Миңа сөлек ярамады-ы, – дип ыхылдаган иде, белекче күкләр күкрәтте: – Синдә чирле кан иде, бәндә баласы! Алар үзләре агу суырды.* Казан утлары

**ЫҺ** *ы.* 1) *к.* **ых**. *Сириненең: «Нигә алар сине озата килмәделәр?» – дип сорыйсы килгән иде дә, авыру әбинең «ыһ-ыһ» дип, чак тын алып ятканын күреп, тыелып калды.* Сөембикә

2) Үкенү, шелтәләү, гарьләнү һ.б.ш. тойгыларны белдерә; *эх. Данутаның галәмгә сыймас олы кайгысы янында Мансурның хәсрәте кечерәеп, әһәмиятсез булып калды, ул ирексездән торып утырырга, нидер эшләргә уйлады, тешен кысып, ыһ! дип куйды.* Казан утлары

◊ **Ыһ дигән** Бернинди дә. *Осталыгы, музыкасының тәэсирлеге берлән халыклар шулкадәр оедылар, залда бер кеше юк кебек, ыһ дигән тавыш ишетелми иде.* Г.Исхакый

**Ы́Һ ИТҮ** *ф. к.* **ыһылдау**. *Карт ыһ итеп куйды да тагын фронт гаменә биреләе.* Г.Гыйльманов

◊ **Ыһ иткән** *к.* **ыһ дигән**. *Мондый солых япон хөкүмәте өчен котелмәгән күсәк булды, ахры, ярты ел чамасы ыһ иткән дә тавыш бирмәделәр.* В.Имамов. **Ыһ та итми** 1) Авырга санамыйча, бер дә авырсынмыйча, җиңел генә. *Бишәр потлы капчыкларны ыһ та итмим.* В.Имамов; 2) Бер дә икеләнмичә, аз гына уйлап та тормыйча. *Ыһ та итмичә риза булу*

**ЫҺҺЕМ** *иярт. к.* **ыһым**. *Керәм дә ыһһем дигән булып тамак кырып куям.* Казан утлары

**ЫҺЫ** *ы.* **1.** *к.* **әһә**. *Ыһы дип уйлый мужик, төнлә йокламауның хикмәте менә нәрсәдә икән.* Ф.Яруллин

**2.** *хәб. сүз мәгъ. сөйл. к.* **әйе** (*1 мәгъ.*). *– Син курайда сызгырыштыра имеш, диләр. Дөресме? – дип, сүзне бөтенләй икенче баштан башлады Өлфәт абзый. – Ыһы, – диде малай, теләми генә, ләкин бу сүзгә һичшиксез тирән аптырап.* Л.Ибраһим-Вәлиди

**ЫҺЫЛДА́У** *ф.* Ыңгырашу. *– Суларга кыен, буылам, – диде кыз, ыһылдап.* Н.Гыйматдинова

**ЫҺЫМ** *иярт.* Җиңелчә йөткерү, тамак кырган тавышны белдерә. *– Ыһым, ыһым, – дип, картларча тамак кырган булды егет.* Р.Кәрами

**ЫЧКЫНДЫРУ** *ф.* 1) Эләгеп торган, бәйләнгән, кысып тоткан, беркетелгән җирдән бушату, җибәрү. *Капитан ым кагуга, башкалар көймәгә ташландылар, ә дигәнче богау йозагын ычкындырып, көймәне ярдан этеп җибәрделәр.* А.Тимергалин. *Азат, куркып булса да, кысланы кармактан ычкындырып, яр буена куя.* А.Гадел

2) Кулны тоткан, тотынган әйбердән, кешедән алу, җибәрү. *Хәзер Садрига ыргакны ычкындырып, ярга ябышып калырга кирәк иде.* А.Вергазов. *– Котны алдың! – диде тегесе, Гүзәлнең кулларын җайлап кына беләгеннән ычкындырып.* А.Гыймадиев

3) Кулдагы әйберне ялгыш яки ирексездән бушатып төшереп җибәрү, тотып тора алмау. *Карасак, малаебызның йөзе агарган, ике кулын тыгып, су читен бутап ята: ай, бичаракай, балыгын ычкындырган...* Г.Ибраһимов. *Кулындагы кылычын кисәк ычкындырып, Туйкә дә атлар арасына егылып төште.* В.Имамов

4) *күч.* Кемне дә булса качыру, качарга ирек кую, мөмкинлек бирү. *Ә бандитлар, атларын кирегә борып алып, качып китәргә маташалар иде инде. «Тере килеш ычкындырмаска кирәк!» – дигән уй йөгереп үтте Миңнулланың башыннан.* В.Нуруллин

5) Тукталып тору, өзелү. *Тулгагы ычкындырганда, дерелдәгән хәлсез куллары белән ишеккә сукты.* Г.Исхакова

6) *күч. сөйл.* Булган мөмкинлектән файдаланмау, шул сәбәпле нәрсәдәндер мәхрүм калу, югалту. *Мондый бәхет адәм баласына гомердә бер генә килә. Шуны кулдан ычкындырсаң, тү-тү, гомерең буе үкенәчәксең.* А.Хәсәнов. *Мондый форсатны кулдан ычкындырсам, үз-үземне гафу итәсем юк!* В.Имамов

7) *күч. сөйл.* Уйламыйча берәр нәрсә турында сөйләү, кирәкмәгән сүз әйтеп ташлау. *Аннан соң, тегe көнне ишегалдында булган хәл турында ычкындырмасмы Хәдис?..* А.Вергазов. *Артыгын ычкындырганымны чамалап, телемне тешләдем.* А.Әхмәтгалиева

8) *күч. сөйл.* Бирү, тарату; тоту, сарыф итү. *Германиягә бик күп ашлык, мамык кертә, үткәрә алса, бакыр да ычкындыра.* Г.Исхакый. *Әптерәшитнең аның акчасы Әнвәрнекенә караганда да күбрәк. Ул бик мулдан ычкындыра. Әнвәр шикелле саран бака түгел.* Г.Камал

9) *күч. гади с.* Эштән чыгару, куу, төшерү. Урыныннан ычкындыру

10) *күч. сөйл.* Башбаштакланырга, тәртипсезләнергә юл кую, мөмкинлек бирү. *Контроль йөгәнен ычкындыру һәм тиешле чара күрелмәү дигәне, илдәге чиге беркайчан да булмастай тоелган инфляцияне сылтау итеп, аптекаларның бәяләрне күз ачып йомган арада да 2–3 мәртәбә арттырып, халыкны кычкыртып талавына юл куйды.* Туган як

11) *күч. гади с.* Үтерү, һәлак итү

**Ычкындыра башлау** Ычкындырырга тотыну. *Гаделҗан, калтырана-калтырана, күлмәк төймәләрен ычкындыра башлады.* Аманулла

**Ычкындыра язу** Чак кына ычкындырмый калу. *Ә син, юләр, кичә киреләнеп, Алла үзе кулыңа китереп тоттырган форсатны ычкындыра яздың.* В.Нуруллин

**Ычкындырып ату** *к.* **ычкындырып ташлау**. *Иң өстенә сала торган куркынычсызлык каешын да ычкындырып аттым.* А.Хәмзин

**Ычкындырып җибәрү** Тиз генә ычкындыру. *Малай бик батырланып кына бүреген салды, бишмәтенең төймәләрен ычкындырып җибәрде.* А.Алиш

**Ычкындырып кую** Ычкындырган хәлдә калдыру. *Шаһи-Морат сыңар кулы белән ике-өч мәртәбә тезенә сугып алды, умырып төшерердәй кискен хәрәкәтләр белән гимнастёркасының өске ике сәдәбен ычкындырып куйды.* В.Имамов

**Ычкындырып ташлау** Һичбер уйламыйча ычкындыру. *Габдулла үзенең гаять беркатлы сорау ычкындырып ташлавын сизеп алды.* Ә.Фәйзи. *Кыз үзе әйтте, үзе кызарынды, кинәтрәк сүз ычкындырып ташлавына уңайсызланды.* А.Гыйләҗев

**Ычкындырып тору** Әлегә, вакытлыча ычкындыру; гел ычкындыру. *Яралы җилкәсе бер әрнеп сызлады, бер җибәреп, ычкындырып торды.* Ф.Бәйрәмова

**ЫЧКЫНУ** *ф.* 1) Эләктереп куелган, ялганган, бәйләнгән, ябыштырылган, урнашкан урыныннан аерылып чыгып китү. *Дары шартлаудан үгездәй*

*олы таш, урыныннан ычкынып, аска тәгәрәгән.* В.Имамов. *Пәрдәләр, каптыргычларыннан ычкынып, идәнгә асылынып төшкән.* З.Мәхмүди

2) Кемнеңдер кулыннан, тотылган, эләккән, бәйләнгән җирдән котылу, аралану, китеп бару. *Шул мәлне Рәния, аннан [Миһәттән] ычкынып, тыкрык буйлап урамга йөгерде.* А.Вергазов. *Әнә бит [балыгың] кармагыңнан ычкынып качты.* А.Әхмәтгалиева

3) Бәйләмнең күзе төшеп калып яки өзелеп сүтелә башлау. *Әгәр син ташласаң, күзе ычкынган оекбаш шикелле, гаиләгез белән таралып китәсез бит.* В.Имамов

4) Су буылган урын ерылу. *Акчишмә үргәсе ычкынган, Сәрмән буасы ычкынган, авыл өстенә ике яклап куркыныч килә.* К.Тинчурин

5) *күч. сөйл.* Китү, кая булса да юнәлү. *Әхәт, хуҗасы кире уйлаганчы дип, ашыга-ашыга, гаражга ычкына.* Р.Миңнуллин. *Вәли Донбасска ычкына, шахтёрга әйләнә.* Р.Зарипов

6) Кая да булса тиз генә качу, ашыгыч качып китү. *Шул чагында малай башын калкытып карады һәм, өметсезләнеп, тешләрен кысты: ычкынып кая бара аласың?* А.Гыйләҗев. *Иншалла, бу юлы да ычкынып өлгердек, ахрысы, ә алдагын белеп булмый, диеп уйланды.* В.Ильясов

7) Кемнән дә булса кинәт читләшү, аралашмый башлау. *Акчаның беткәнен сизгәч, Хәсәншаның иң якын күргән дуслары да берәм-берәм ычкындылар.* Ш.Мөхәммәдев

8) *күч.* Берәр төрле авыр, кыен хәлдән чыгу, нәрсәнеңдер тәэсиреннән, йогынтысыннан котылу. *Ул бит сугышның эченнән, Газраилнең үлем чалгысы астыннан, үлем авызыннан ычкынып кайткан.* Г.Бәширов. *Хәлим яхшы белә: аның гадәти әпә генә булмавын да, теләсә кайсы вакытта, урман сихереннән ычкынып, кешеләр арасына кайтырга теләячәген дә белә иде.* Г.Гыйльманов

9) *күч.* Тиешенчә файдалана, тота белмәү аркасында юкка чыгу, таркалу, әрәм-шәрәм булу, бетү. *Гөрләп барган сәүдә эше, чыңлап тиенгә-тиен кушылып торган саф табыш чыганаклары, Мирзахан бай түшәккә менү белән, күзгә күренеп ычкынып таркала башлый...* М.Хәсәнов

10) *күч.* Югалу, юкка чыгу, китеп бетү. *Кулыннан дәүләт ычкына, шуңа котыра ул.* В.Имамов

11) *күч.* Ирексездән яки уйлап бетермичә ни дә булса әйтелү, ялгыш сөйләнү, эшләнү. *Хата арты хата ычкына.* М.Шабаев. *Ә минем ул сүз ычкынып өлгергән иде.* Р.Кәрами

12) *күч.* Эш урыныннан чыгарылу, куылу, төшерелү. *Кибет янганнан соң директорлыктан ычкынсам да, мөнәсәбәтләр үзгәрмәде.* Казан утлары

13) *күч.* Тыелып торудан туктап, үзенә ирек кую, башбаштаклану, тәртипсезләнү. *Ычкыныр чаклары җиткәндә, алар әнә шулай һәркемгә бәйләнәләр.* Казан утлары

14) *күч. гади с.* Үлү, һәлак булу. *Мин теге ни... и-һи-и, ычкына бу мескен дип тора идем. Үзәгең нык икән, малай.* Г.Әпсәләмов. *Әнә дөньяда иң бай саналган корольләр ычкына гүргә.* Ф.Баттал

15) *күч. сөйл.* Акылы җиңеләю, юләрләнү; тәртипсезләнү, үзен башкалардан үзгә тоту. *Мин андый очракларда ычкынып, бик нык әшәкеләнеп тә алгаладым һәм бүгенгәчә үземне андый тәртипсезлегем өчен уңайсыз хис итәм.* Р.Гаязетдин

16) **ычкын** *боерык ф. форм.* «Тизрәк кит», «моннан югал» мәгънәсендә. *– Бар, энекәш, ычкын исән чакта! – диде Сафиулла агай, коты алынып.* В.Нуруллин

**Ычкына башлау** Ычкынырга тотыну. *Юкса кирәксез, күңелгә ятышсыз сүзләр күп ычкына башлады.* Ф.Дәүләтбаев

**Ычкына язу** Чак кына ычкынмау, әздән генә ычкынмый калу. *Бөтенләй ычкына яздым. Аракы шаукымыннан да хәтәррәк булып чыкты бу сихер дигәннәре...* Г.Гыйльманов

**Ычкынып алу** Азга, кыска вакытка гына ычкыну. *Елына өч-дүрт мәртәбә ычкынып ала инде шулай.* Д.Булатова

**Ычкынып бару** Ычкына башлау. *Көндәшемнең әллә ычкынып бара инде бу хатын дип уйлавыннан шикләнеп, тәмам пошаманга төштем бит.* Г.Галиева

**Ычкынып бетү** Тәмам, тулысынча, барысы да ычкыну. *Мирвәли бөтенләй ычкынып бетә алмады, аны кабат эләктереп алдылар, җиргә ектылар.* Г.Гыйльманов. *Тегенең --- ычкынып беткән төймә-каптырмаларын эләктерергә азапланган арада, үземнең дә бармак очларым тоймас хәлгә килгән иде инде...* М.Садыйков

**Ычкынып калу** Мөмкинлек барында яки ни дә булса килеп чыкмас борын ычкынырга өлгерү. *Яхшы чакта ычкынып калыйк.* А.Гыйләҗев

**Ычкынып китү** Кинәт ычкыну. *Ә, аңа китап җене кагылган, ара-тирә шулай ычкынып киткәли ул.* Г.Бәширов. *Егылган егетнең --- бүреге, башыннан ычкынып китеп, әллә кая атылып барып төште.* М.Гали

**Ычкынып тору** Әлегә, вакытлыча ычкыну. *Иң шәбе сиңа утраудан ычкынып торырга иде.* А.Гыйләҗев

**ЫЧКЫР** *и. сөйл.* Ыштан бавы. *Бу уй аны бераз тынычландырса да, Балҗан сәкегә килеп утырырга кыймады, аулакта хәнҗәрен олтырак астыннан алып ычкырга тыкканнан соң, почмакка барып сөялде.* Т.Әйди

**ЫЧКЫРЛЫ** *с.* Ычкыры булган, ычкыр белән бәйләнә торган. *Өс-башы ташка үлчим: ямау өстенә ямау чәпәлгән тышсыз кыптыр кыска тун, башында чите камалы мескен бүрек, төбе асылынып торган ычкырлы киндер ыштан.* М.Хәсәнов

**ЫШ** *иярт.* **1.** 1) Җил искән тавышны белдерә

2) Нәрсә дә булса ышкылган яки камчыны, чыбыркыны һаваны кисеп кискен селтәгән вакытта чыккан тавышны белдерә

**2.** *ы. мәгъ.* «Шаулама» дигән мәгънәдә әйтелә. *«Ыш-ш-ш!» – диләр, шауларга ярамаганны аңлаталар. Больница халкы йоклый, тынычлык сакларга кирәк.* Казан утлары

**ЫШАНДЫРГЫЧ** *с.* **1.** Ышандыра торган, шикләнергә урын калдырмый торган. *Тәүфикъ Әйдигә иң беренче чиратта ышандыргыч дәлилләр белән эш итү хас.* Б.Рәхимова

**2.** *рәв. мәгъ.* Ышандырырлык итеп. *Реализм юнәлешендә иҗат итүче сәнгатьче бигрәк тә халкының көнкүрешен ышандыргыч тасвирлый.* К.Гыйззәтов

**ЫШАНДЫРУ** *ф.* 1) Нәрсәнең дә булса дөреслегенә, раслыгына инандыру. *Моны, билгеле бер дәрәҗәдә бәхеткә каршы, Акчәч үзе дә, язучы да бик яхшы аңлый һәм укучыны да һичшиксез ышандыра.* Ф.Урманче. *Алай дисәң, Ак бабайның сүзе дә ышандыра кебек – һава дымлы, бөркү, чык та мул төшә.* Г.Гыйльманов

2) Кемгә яки нәрсәгә дә булса ышаныч тудыру, ышаныч уяту. *Димнә күңелендә фикер итте: бу сүз Шәтрәбәгә җитсә, шунда ук килеп, үзенең арулыгын исбат итәр һәм урынлы сүзләр белән хыянәтсезлегенә Арысланны ышандырыр.* Ибн әл-Мөкаффаг

3) Вәгъдә итү, сүз бирү; өметләндерү. *«Боерыңыз», – дип, теләгебезне үтәргә ышандырып, безне мөсафирханәсенә китерде.* К.Насыйри. *Ә сатучы абзый кайчан да булса минем сепаратка мотор табып бирәм дип ышандыра...* А.Гыйльми

**Ышандыра башлау** Ышандырырга керешү. *Идел – Чулман – Агыйдел буйларындагы халыкның Карабәк кавеменнән яралганлыгына ышандыра башлый.* Казан утлары

**Ышандыра төшү** Тагын да ныграк ышандыру. *Купчелек атамаларның антропонимнар яки кеше исемнәреннән килеп чыкканлыгын искә алсак, бу атаманың Алыпбай исеменнән чыкканлыгы ышандыра төшә.* И.Хуҗин

**Ышандырып бетерү** Тәмам ышандыру. *Бу сүзләр, билгеле, егетне ышандырып бетермәде.* З.Хөснияр

**Ышандырып җитү** Ахырга кадәр ышандыру. *Мостафинны аның сүзләре ышандырып җитмәде бугай, ул, тиз генә өстәл яныннан торып, кәгазьләрен тартмага бикләде, шинелен киде, каешын бәйләде һәм ишеккә атлады.* Х.Камалов

**Ышандырып карау** Ышандырырга омтылу. *Ә сезне, бар, ышандырып кара.* Г.Гайнуллина

**Ышандырып кую** Алдан ук ышандыру. *Ниһаять, комиссия көне билгеләнә, Сабитов: «Синең әсәрләрең мотлак үтәчәк, шундый шәп хикәяләрең бар бит», – дип, Заһитны алдан ышандырып куя.* З.Мурсиев

**Ышандырып тору** Һәрвакыт, гел ышандыру. *Аның салмак табигате, ашыкмыйча, сүз кадерен белгән бай, образлы сөйләме холкына ятышып, табигатьтә гармония, илаһи иплелек барлыкка ышандырып тора.* Т.Галиуллин

**ЫШАНДЫРЫРЛЫК** *с.* Ышаныч тудыра торган, ышанырлык. *Минем дәлилләрем ышандырырлык түгел идемени?* А.Вергазов

**ЫШАНМАЛЫК** *и.* Сәүдә эшендә товар бәясенең алдан биреп куела торган өлеше; *русчасы:* **задаток**

**ЫШАНМАСЛЫК** *с.* **1.** Ышанып булмый торган, ышанырга мөмкин булмаган. *Кеше ышанмаслык нәрсә инде бу.* А.Хәлим

**2.** *и. мәгъ.* 1) Ышанмау халәте. *Минем аңа ышанмаслыгым юк, тик күзгә күренеп үзгәргәч, ни дип тә аңлата алмыйм.* Саба таңнары

2) Ышанырга мөмкин булмаган хәбәр яки сүз. *Гомумән, солдатның моның ише искә төшереп сөйләр әкәмәт нәрсәләре күп була. Ышанырлыгы да, ышанмаслыгы да...* Ә.Еники

**ЫША́НМАУЧЫЛЫК** *и.* 1) Ышанмау хәле, ышанычы булмау, шикләнеп карау гадәте; шикләнүчәнлек. *Булат аңа [Сәфәр бабайга] текәлеп карады, таный алмады: «Юри киенгән берәр шпик түгелме бу карт убыр?» – дип, гадәттәге ышанмаучылык чаткысы аның миеннән йөгерде.* Г.Ибраһимов

2) Өметсез караш, нәрсәнең дә булса мөмкинлегенә яки чынлыгына ышанмау хәле; скептиклык. *Ә синдә кешеләргә ышанмау ни сәбәпле шушы кадәр көчле? Каян килде мондый ышанмаучылык?* З.Хәким

**ЫШАНУ** I *ф.* 1) Хакыйкать дип кабул итү, чынлыгына, дөреслегенә инану, шикләнмәү. *Дин һәм фән һич тә бер-берсенә каршы торучы системалар түгел, табигать белгече булган хәлдә дә, табигатьтән өстен көчләргә ышанырга мөмкин икән.* А.Тимергалин

2) Эш яки хәлнең булачагына өметләнү, өмет баглау, уңышлы башкарылуына ышаныч белән карау; инану, исәп тоту. *Беренче көннәр бик авыр булса да, без мәкерле дошманны җиңәчәгебезгә, эшебезнең хак икәнлегенә, урамыбызда бәйрәм булачагына тирәнтен ышандык, – дигән иде.* Ш.Мостафин

3) Кемгә дә булса ышаныч баглау; ышанычлы санау, өметне акларлык дип уйлау. *Байбичә бу картны яратмый һәм аңа ышанмый иде.* Г.Ибраһимов. *Тик мин сиңа ышанам, Саҗидә, сынатмассың дип уйлыйм.* Г.Галиева

**Ышана бару** Торган саен күбрәк ышану. *Бар язган әйберләрен барлап чыксаң, аның бөек шагыйрь икәнлегенә торган саен ышана барасың...* Р.Миңнуллин

**Ышана башлау** Ышану билгеләре барлыкка килү. *Канәфер агачы әкренәкрен әлеге сүзләргә ышана башлый.* Г.Рәхим

**Ышана бирү** Һаман да ышануын дәвам итү. *Менә шушы фактларга да карамастан, күбәүләр «Беркетмәләр»нең чынлыгына ышана бирәләр.* А.Тимергалин

**Ышана төшү** Тагын да ныграк ышану. *Киңәшеп, сөйләшеп алгач, үз-үзеңә ныграк ышана төшәсең.* М.Вәлиев

**Ышанып бетү** Тәмам, тулысынча ышану. *Маратка ышанып бетәргә ярамый.* А.Гыймадиев. *Ул шундый җаваплы эшне энесенең башкарып чыгуына ышанып бетми иде.* А.Вергазов

**Ышанып җитү** Ахырга кадәр ышану. *Нәркизә дустына ышанып җитми, ләкин Фатихны сынап карыйсы килә.* Ф.Яруллин

**Ышанып кую** Кинәт ышану. *Мактама, йә ышанып куярмын.* Ф.Яруллин. *Аның фантазиясе кайчандыр Җиргә килгән марсианнар, ерак йолдызлардан килгән могҗизалы затлар турында әкиятләр, ышанмас җиреңнән ышанып куярдай легендалар уйлап чыгара.* А.Хәсәнов

**Ышанып тору** Һәрвакыт, гел ышану. *Гүя ул сабыр гына нидер көтә, нәрсәгәдер ышанып тора.* Ә.Еники

**ЫШАНУ** II *и. мәгъ.* Төрле ырымнарга нигезләнгән гореф-гадәт, йола, киләчәкне юрау. *Халыкта ахшамнан соң өй җыештырырга, идән себерергә ярамый дигән ышану бар.* А.Тимергалин

**ЫШАНУЛЫ** *с.* 1) Икеләнүсез, тәвәккәл, кыю. *Бурбонның кыяфәте тыныч, кодрәтле, үз-үзенә ышанулы иде.* Казан утлары

2) Ышанган, ышаныч белдерә торган. *Ул, яп-якты зәңгәр күзләрен зур итеп ачып, сабыйларга гына хас үтә ышанулы тавыш белән сузып кына сорау бирергә дә өлгерде.* Ф.Сафин. *[Аның] Йөзендә – холкына хас үз-үзенә ышанулы йомшак елмаю.* А.Хәсәнов

**ЫШАНУЧАН** *с.* **1.** 1) Табигате, холкы белән җиңел, тиз ышана торган, эчкерсез; самими, беркатлы. *[Ике көчекнең] Берсе тешләк, усал һәм үчле булса, икенчесе самими, ышанучан һәм күңелчән иде.* Г.Гыйльманов. *Кичерегез, беркатлы кеше дип безнең якларда тиз ышанучан самимиләргә әйтәләр.* К.Кәримов

2) Ышануын күрсәтеп торган, ышаныч белдергән. *Мин аны [сабыйны] нығытып күкрәгемә кыстым, аның --- ышанучан саф күзләренә тутырып карадым.* Н.Фәттах

3) Ышануга нигезләнгән, ачыктанәчык. *Аның белән ышанучан мөнәсәбәт булдырыгыз, үз эченә бикләнүенә юл куймагыз, аңа хәлегездән килмәгәнне вәгъдә итмәгез – бу сезгә ышанычны какшатырга мөмкин.* Р.Мәтҗанова

**2.** *рәв. мәгъ.* Ышаныч белдереп, ышаныч белән. *Хатыны түгәрәк йөзле, күзләре ышанучан карый, елмайганда бигрәк тә ягымлы.* М.Хуҗин

**ЫШАНУЧАНЛЫК** *и.* Ышану гадәте, ышанучан булу үзлеге. *Кызганычка каршы, еллар үтү белән кыяфәте үзгәрсә*

*дә, күз карашы, йөзендә чалынган рух рәвеше үзгәрмәгән Эльвирның, аның яшькелт күзләре әле һаман балаларча беркатлылык, сафлык, ышанучанлык белән ярдәм сорап карыйлар.* М.Маликова

**ЫШАНЫРЛЫК** *с.* Ышанырга мөмкин булган, ышаныч уята торган. *Әгәр гыйлеменә, диненә, тәрбиясенә ышанырлык кеше тапсалар рөхсәт итәрләр, дигән уйда торам.* Г.Баруди

**ЫШАНЫЧ** *и.* 1) Нинди дә булса идеягә, фактка, берәр кешегә яки нәрсәнең дә булса сыйфатына ышану хәле. *Язучы әсәренең идеяләре киләчәккә никадәр ныграк бәйләнгән булса, ул әсәрнең вакыт узу белән искермәячәгенә шуның кадәр ышаныч бар.* М.Мәһдиев. *Бу кара күзләр аңа ышаналар, ул – бар нәрсәгә сәләтле гаярь егет, бары тик кара кашлар астындагы әнә шул кара күзләрдә аңа булган ышаныч кына сүнә күрмәсен!* З.Хөснияр

2) Теләгән, уйлаган нәрсәнең тормышка ашуына исәп тоту, шикләнмәү хәле; өмет. *Бездә ышаныч бар, бездә яшьлек бар, без аларны табарга тиеш. Без тугры юлны табарга тиеш.* Г.Исхакый. *Аның --- бераз артка чөелгән йөзендә киләчәккә ышаныч, өмет һәм ихтыяр көче сизелеп тора иде.* А.Хәлим

3) Кемнең дә булса эчкерсезлегенә, намуслылыгына, сәләтенә шикләнмәү, шуңа нигезләнгән мөнәсәбәт. *Безне шаулап торган яшьлегебез, тормышны ярату, бер-беребезгә ышаныч берләштерде бугай.* А.Нәҗми. *Бу инде ике арада килешү, ышаныч барлыкка килгәнлеген белдергән билге иде.* В.Имамов

◊ **Ышаныч вотумы** *махс.* Хөкүмәт яки министр эшчәнлегенә хуплау белдерә торган парламент карары. *Узган атнада Греция[дә] --- Г. Папандреу хөкүмәте парламентта ышаныч вотумы алуга иреште.* Мәдәни җомга. **Ышаныч грамотасы** Дипломатик вәкилләргә бирелә торган рәсми таныклык. **Ышаныч баглау** Өмет итү, ышанып көтү. *Иseme танылып кына килгән яшь язучыга өлкәнрәк буын әдипләр зур ышаныч баглыйлар.* Н.Гамбәр. **Ышанычка алу** Ышанычтан чыккан кешене үз җаваплылыгына алу; *русчасы:* **взять на поруки**. *Шуннан бервакыт хәбәр итәләр: атаң зур сәяси эш белән чекага эләкте, җинаяте өлкән, әгәр ышанычка алсаң, язмышы җиңеләюе мөмкин, диләр.* Г.Ибраһимов. **Ышаныч казану** Үзенә ышандыру, ышанычлы булуын исбатлау. *Үзара ышаныч казангач, әкренләп иске китапларны алардан алып торгаларга һәм ят кешегә бик күрсәтми генә укырга мөмкинлек туды.* А.Тимергалин. **Ышанычка керү** 1) *к.* **ышаныч казану**. *Кешене куркытып тыеп булмый икән, башка төрле юл белән, ышанычка кереп коралсызландырырга кирәк...* Ф.Бәйрәмова; 2) Хәйлә, алдау юлы белән кемнең дә булса ышанунына, уңай мөнәсәбәтенә ирешеп, астыртын эш йөртү. Син *аның «тәүбә иттем» дигән сүзенә карап алданма, аннан иман көтмә, ышанычка керер өчен генә тырыша ул.* Н.Исәнбәт. **Ышанычтан чыгу** Үзенә булган уңай мөнәсәбәтне акламау, ышанычсызга әйләнү. *Аннан соң да төрле хәлләр булды, бохаралылар да ышанычтан чыга башлады.* Казан утлары

**ЫШАНЫЧЛЫ** *с.* 1) Ышаныч тудыра торган, ышанырлык. *Хатны ышанычлы кешеләр артыннан гына йөртергә туры килә, югыйсә эзгә басалар.* А.Алиш. *Бу юха елан шәхси конфликтны ырулар мөнәсәбәтенә күчерә, алар арасына таркаулык кертә, илнең терәге, ышанычлы сакчысы, арка таянычы булган зирәк, туры сүзле гаскәр башлыгы Туңгак алыпны дәүләт эшләреннән читләштерүгә, имгәтеп ташлауга ирешә.* Ф.Хатипов

2) Билгеләнгән вазифасына, таләпләргә җавап бирә алырлык, куркыныч янамый торган; нык, бирешми торган. *Гастрольләргә киткәндә, капчыкны, идән тактасын каерып, аска яшерә идем. Бу да ышанычлы урын түгел иде. Хәйләкәр караклар бер иснәнсә, диварыңа хәтле сүтә икән.* Н.Гыйматдинова. *Шәһре Болгарны ышанычлы ныгытмалар белән уратып алалар.* Казан утлары

3) Максатка ирешү өчен уңай, дөрес булган. *Аныңча, моңа ирешүнең иң ышанычлы юлы – Искәндәр ахунның җиләктәй сылу кызы Гайшәгә өйләнеп җибәрү һәм ахун кияве сыйфатында бай мәхәлләдә имам булып калу.* Ф.Хатипов. *Татар теленең диалектларын өйрәнүнең камил һәм ышанычлы алымнарыннан берсе – лингвистик география ысулы.* Д.Рамазанова

4) Өметле, киләчәге ачык билгеле булган. *Болай бары тик киң күңелле, бүгенгесе һәм киләчәге нык, ышанычлы булган кешеләр генә көләләр.* Г.Әпсәләмов

5) Нык, тыныч, икеләнүсез. *Малай, сихерләнгән шикелле, беркавым юл читында басып торды, аннары, ниндидер боерыкка буйсынгандай, сулга борылып, ышанычлы адымнар белән юлын дәвам итте.* А.Тимергалин. *Хәзер беләбез аны дигән ышанычлы кыяфәт белән председатель кесәсеннән шырпы кабы чыгарды да камылны үлчи дә башлады.* Р.Миңнуллин

6) Үзенә ышанычы сизелеп торган. *– Юк, син кул селтәмә, – диде Рәфис ышанычлы тавыш белән.* А.Вергазов. *Дарулар белән генә түгел, ышанычлы сүзе, төпле киңәшләре, тәмле теле, яхшы күңеле белән дә дәвалады ул.* Шәһри Казан

7) Ышаныч белдереп торган, ышаныч билгеләре күренгән. *Авторның [Гаяз Исхакыйның] телгә карата мондый ышанычлы карашы ул чор өчен урынлыдыр.* Х.Миңнегулов. *[Аның] Йөзенә ышанычлы елмаю йөгерде.* Ф.Яхин

8) *күч.* Исбатланган, абруйлы. *Хәзергә вакытта, кулда ышанычлы дәлилләр булмаган хәлдә, галимнәр коллективы, Атлантиданы эзләү өчен, махсус экспедицияләр оештырмаячак, әлбәттә.* А.Тимергалин

**2.** *рәв. мәгъ.* Ышандырырлык итеп, шик калдырмыйча. *Аның дәлилләре бик ышанычлы яңгырый. А.Әхмәдуллин*

**3. ышанычлысы** *и. мәгъ., тарт. форм.* Кемнең дә булса исеменнән эш итәргә хокукы булган, шуның өчен рәсми билгеләнгән кеше. *Григорий Украинаның халык артисты, язучылар ширкәте әгъзасы, Украина Президентының шәхси ышанычлысы булуы турындагы таныклыкларын кулыннан ычкындырмыйча гына күрсәтте.* А.Хәлим

◊ **Ышанычлы вәкил** *к.* **ышанычлысы**. *Мәгълүматлар базасына керергә рөхсәт алу өчен, үзең белән паспортыңны алып килергә кирәк; ышанычлы вәкил ярдәмендә эш иткәндә, ышаныч язуы булу мәҗбүри.* Биектау хәбәрләре

**ЫШАНЫЧЛЫК** *и. к.* **ышаныч язуы**

**ЫШАНЫЧЛЫЛЫК** *и.* Ышанычлы булу үзлеге. *Дөреслек, ышанычлылык бөтен фазыйләтләрнең анасы икәнлеге мәгълүм.* Р.Фәхретдин. *Бауның ныклыгын, ышанычлылыгын тикшерәләр.* Р.Мөхәммәдиев

**ЫШАНЫЧНАМӘ** *и. рәсми* Икенче кешегә үз исемеңнән эш йөртү өчен бирелә торган махсус язу, таныклык

**ЫШАНЫЧСЫЗ** *с.* 1) Ышанычы булмаган, кемгә дә, нигә дә ышанмаган. *Чөнки кешедә нинди дә булса ышаныч яшәргә тиеш, югыйсә ышанычсыз кешеләрнең кыйблалары юк.* А.Нәҗми

2) Ышаныч тудырмый торган, таянырга мөмкин булмаган. *Кечкенә нәрсәдә ышанычлы булган [кеше] зур нәрсәдә дә ышанычлы булыр, ә кечкенә генә нәрсәдә ышанычсыз булган [кеше] зур нәрсәдә дә ышанычсыз булыр.* Инҗил

3) Шикле, өметсез, скептик. *Кайчагында автор бер ышанычсыз гипотеза өстенә икенчесен кора, һәм аның фикер сөреше --- тагы да тотрыксызрак була бара.* А.Тимергалин

**ЫШАНЫЧСЫЗЛЫК** *и.* 1) Кемне дә булса ышанычсыз дип уйлау, кемгәдер ышанмау хәле. *Ләкин, ни генә сизенмәсен, хан аңа карата салкынлык, ышанычсызлык төсмере күрсәтмәде, һаман да иң тугры ярдәмчеләреннән санап килде.* В.Имамов

2) Ышанычлы булмау, хыянәткә сәләтлелек, тугрылыксызлык. *Әмма күз карашында мәкер һәм ышанычсызлык галәмәтләре калганлыгын Корытай Хафиз өченче күзе белән сизенә иде.* Ф.Яхин

3) Өметсезлек, пессимизм. *Бүген булмаса, иртәгә зур тышкы куркыныч ябырылуын көтеп, сиземләп яшәү, шуннан туган ышанычсызлык, өметсезлекләр халыкның рухын, сәләтен, иҗат көчен юкка чыгара бара.* М.Гайнетдин

◊ **Ышанычсызлык вотумы** *махс.* Дәүләт хокукында: берәр органның яки аның аерым әгъзаларының эшчәнлеген хупламауны белдергән, тавыш бирү юлы белән кабул ителгән карар

**ЫШАНЫЧ ЯЗУЫ** *и. к.* **ышанычнамә.** *Кесәләрнең берсеннән правасы, техпаспорт һәм Дягилев дигән кеше исеменнән аңа бирелгән ышаныч язуы килеп чыкты.* Ә.Сафиуллин

**Ы́Ш ИТҮ** *ф.* Җил исү. *[Җил] Ыш-ыш-ш итте, җирне сыйпады, үләннәрне аралады, сары яфракларны кузгатты.* Г.Сабитов. *Ыш иткән җил, тавыш юк, күк йөзе, әнием юган тәрәзә өлгеседәй, чалт аяз иде.* Кызыл таң

**ЫШКУ** *ф.* Ике әйберне бер-берсе өслегеннән әрле-бирле йөртү яки берсен икенчесе өслегеннән каты басып шудыру. *Бәрәңгене дә әрчеп тору юк, чалбар балагына ышкып, көлен генә кагып төшерәсең дә, әйдә аша!* А.Гыйләҗев

**Ышкый башлау** Ышкырга тотыну. *Лампаны чүпрәк белән ышкый башлауга, җир тетрәп китте һәм аның каршына бик зур гәүдәле бер җен килеп басты.* Әкият

**Ышкый төшү** Тагын да ныграк ышку

**Ышкып алу** Тиз һәм аз гына ышку *– Үзем барып яхшы иттем әле, – диде Шәйхи абзый салмак кына һәм кул сырты белән яңагын ышкып алды.* Ә.Еники

**Ышкып бетерү** Барысын да яки беткәнче ышку. *Ышкып бетергәч, каләмен карага манып, анда нәрсәдер язып куя.* Әдипләр

**Ышкып җибәрү** Бераз гына ышку. *Кайрак та әйбәт иде, ике генә ышкып җибәрәсең... – чалгының йөзе шундук җаныңны кырып алырлык хәлгә килә...* Г.Гыйльманов

**Ышкып карау** Сынау максаты белән ышку. *Алар бармакларын дегеткә манып алып, дегетне уч төпләренә ышкып карыйлар, сатулашалар, бәһасен килешсәләр, дегет агызырга чиләкләрен китереп куялар.* М.Галәү

**Ышкып кую** Кинәт һәм тиз генә ышку. *Абзый кеше ямаулы тез башларын ышкып куйды.* Ә.Еники

**Ышкып тору** Һәрвакыт, гел ышку; әле, хәзерге вакытта, күз алдында ышку. *Аит, бик тырышып, аклы-кызыллы йомшак аяк киемен чүпрәккә ышкып торды.* Ә.Гаффар. *Сул кулының учыннан ниндидер кайнарлык бәрүе беленгәч, әниләре аңа гарип кулын гел ышкып торырга кушты.* Ф.Садриев

**Ышкып чыгу** Башыннан ахырына кадәр яки һәрберсен бер-бер артлы ышку. *Чистартылган һәм эшкәртелгән казның тышын һәм эчен әйбәтләп тоз һәм борыч белән уганнан соң, бөтен җирен сарымсак белән ышкып чыгарга кирәк.* Казан утлары

**ЫШКЫ** *и.* Агач өслекне шомарту өчен озынча кысага киң һәм очы үткен йөзле тимер кискеч пластинка куеп ясалган эш коралы. *– Мин үзем дә балконга гөлләр утыртырга кызыгып йөрим, – диде Галимә, – әллә ничә тапкыр әйтеп карадым, йә такта юк, йә ышкы юк, дип, сылтау таба.* Ф.Яруллин

**ЫШКЫЛА́У** *ф.* 1) Агач материалны ышкы белән шомарту, тигезләү. *Верстагы янында көне буе кисеп, юнып, ышкылап әллә никадәр эш эшләгәннән соң, түр башындагы ястыкка кырын ятуы аңа бик килешә иде.* Г.Бәширов. *Күрәсеңме, бөтен эшләрне эшләде: утынны ярып бетерде, такталарны ышкылап, койманы какты.* З.Хәким

2) *к.* **ышку**. *Надияне алдан авыр кабул итсә дә, ташка таш ышкылап шомарган шикелле, Әнисә аңа күнекте, ияләште, ахыр чиктә алар авызга авыз куеп, гел серләшеп, чөкердәшеп яши торган ахири дуслар булып киттеләр.* Т.Галиуллин

**Ышкылап алу** Аз гына яки тиз-тиз ышкылау

**Ышкылап бетерү** Барысын да, ахырга кадәр ышкылау

**Ышкылап җибәрү** Берәз ышкылау. *Сүтеп, ышкылап җибәрсәң, яңадан мең елга түзәрлек.* Ф.Яруллин

**Ышкылап кую** Алдан ышкылап калдыру. *Ә беркөнне, ни күрим, атаң ышкылап куйган үзен, ялт иттереп.* Ф.Яхин

**Ышкылап тору** Әле, хәзерге вакытта, күз алдында ышкылау

**Ышкылап чыгу** Башыннан ахырга кадәр, барысын да бер-бер артлы ышкылау

**Ышкылый башлау** Ышкыларга керешү

**Ышкылый төшү** Тагын да ныграк ышкылау

**ЫШКЫЛУ** *ф.* 1) Берәр нәрсәгә бәрелеп, кагылып, орынгалап тору, шуып узу. *Очы-кырые күренмәгән бу күкрәп үскән иген шулкадәр якын, хәтта башакларның бер-берсенә ышкылып кыштырдаулары ишетелә.* Ә.Еники. *Якыннан гына трамвай гүләп узды, тимер тәгәрмәчләр, борылышта рельсларга нык ышкылып, сызлангандай чыелдады.* М.Маликова

2) *күч. сөйл.* Кыршылып ялтырау; сизерәп бетү, сүсәреп тору. *[Гаделҗан бабай] --- озак гомерләр юуны күрмәгәнлектән каралып кына түгел, карасы ышкылып ялтырап беткән сырган чалбарын --- «сочинкәсенә» кыстырып, --- яңа яуган карны шыгырдатып таптап, түбән очка таба кузгалды.* Л.Ибраһим-Вәлиди

3) *күч. гади с. к.* **ышкыну** (*2 мәгъ.*). *[Песи] Койрыгын өскә тырпайтып, башын күтәреп, хуш килдегез, рәхим итегез дигәндәй, аякларыбызга ышкылып иркәләнә башлады.* Г.Мөхәммәтшин. *Зәүҗә башым белән йөрмәс идем, тәхет тирәсендә ышкылып.* З.Мансуров

**Ышкыла башлау** Ышкылырга тотыну. *Аякларым да кыбырҗый, үзеннән-үзе идәндә ышкыла башлады.* Казан утлары

**Ышкылып алу** Аз гына ышкылу. *Тотыш би каегын[ың] --- сумалалы биек кырые белән акбүреләр каегының кызылга буялган борынына ышкылып алды.* Н.Фәттах

**Ышкылып бетү** Тәмам, бик нык ышкылу. *Яшьләр белән шулай көлешеп-сөйләшеп торганда, кибеткә, ышкылып*

*беткән кара портфель тотып, күзлекле бер кеше килеп керде.* Н.Фәттах

**Ышкылып китү** Кинәт ышкылу. *Шулчакта мәгъриб кешесе кигерткән балдак очраклы рәвештә ышкылып китте.* Әкият

**Ышкылып тору** Әле, хәзерге вакытта ышкылу. *Шул зират өстендә Әтрәч карьясенең сыер-сарык көтүе йөргәнен күрдек, бәгъзы хайваннар ташлар арасына ятканнар, бәгъзылары ташка ышкылып торалар.* Безнең мирас

**ЫШКЫНУ** *ф.* 1) *кайт. юн. к.* **ышку**. *Сыер ышкынса, читән аудара.* Мәкаль. *Кыш көне кар белән ышкыну, салкын су белән юыну кешене салкынга күнектерә.* Т.Гыйззәт

2) *күч. гади с.* Берәр максат белән кемнең дә булса тирәсендә буталу, әйләнеп-тулганып йөрү. *Биредә ышкынып йөрмәгез, ишеттегезме? Барыгыз, бар, күздән югалыгыз.* М.Шабай

**ЫШНА** *и. иск.* Урманны төпләп, яндырып, агач төпләреннән арындырып әзерләнгән чәчүлек җире. *Искил атлы ыру бабаларыбыз ошбу эргәгә иңгәннәр дә, йөзәр еллык имән илә карагайларны аударып, ышна арчыганнар.* В.Имамов

◊ **Ышна ачу** Ышна җире әзерләү. *Урманнарны төпләп яндырып, ышна ачып иген иккәндә, ботак-сатак, агач төпләре әледән-әле яндырылып торганда, мондый хәлләр [торф кабынып, айлар буе җир астында пыскып яну очраклары] аз булмагандыр.* Казан утлары. **Ышна җире** *к.* **ышна**. *Урман кисеп ачылган ышна җирләре бик тиз уңдырышсызланган.* Б.Хәмидуллин

**ЫШТ** *иярт.* Кинәт өзелеп калган сызгыру тавышын белдерә

**ЫШТАН** *и.* Гәүдәнең билдән түбәнге өлешен каплап тора торган балаклы өс киеме. *Әле беренче тапкыр гына киелгән ак күлмәк, кызыл киҗеле кыска киндер ыштан белән өстенбашын бөтәйтеп алган.* А.Хәлим

**ЫШТАНЛЫК** *с.* **1.** Ыштан тегү өчен билгеләнгән. *Ыштанлык бумази*

**2.** *и. мәгъ.* Ыштан тегү өчен билгеләнгән материал. *Эрләмәгән-сукмаган, Хөбби, сиңа ыштанлык.* Әйтем. *Хатыннары, үзләренә киемлек, ыштанлык шикелле нәрсәләр сугып, өс-башларына үзләре әзерлиләр.* Р.Зарипов

**ЫШТАНСЫЗ** *с. гади с.* **1.** 1) Ыштаны булмаган. – *Әтиең нишли? – дип сорый иде ул, ыштансыз малайны очраткан саен.* А.Хәлим

2) *күч.* Киеме артык ачык, кыска, артык шәрәләнгән. *Дискотекаларда ыштансыз кызлар тирәсендә бөтерелеп, тирә-ягындагы тыйнак кызлардан коры калган Зиннурның хыялы да бик табигый.* Акчарлак

3) *күч.* Артык юмарт. – *Кем бирде ул акчаларны? – дип сорый Равил. – Гөлсем апа! – ди балалар. – Һәй, Гөлсем шулай ыштансыз инде ул! – ди Равил.* Р.Батулла

4) *күч.* Ярлы, хәерче. *Чыбыркысы белән меңәр баш сыер куаласа да, көтүчебез ыштансыз иде. Халыкка бил бөгүче мантымый ул, нужәли син шуны аңламыйсың, кызый?!* Н.Гыйматдинова

**2.** *рәв. мәгъ.* Ярлы, хәерче хәлдә. *Барысына төкереп, ыштансыз яшәргә дә булыр иде, ләкин гаилә бар, балалар бар.* З.Хәким

◊ **Ыштансыз калу** Бөлү, бөлгенлеккә төшү. *Монда бер көндә баерга һәм ярты сәгатьтә ыштансыз калырга була.* З.Мәхмүди. **Ыштансыз (йөргән) чакта** Балачакта, кечкенә, сабый чакта. *Аңлашуның мондый төре үзара шактый якын кешеләр арасында гына була торгандыр. Мәсәлән, ыштансыз чактан ук бергә әүмәкләшеп, әвәрә килеп үскән авылдаш-яшьтәшләр арасында.* З.Хөснияр

**ЫШТАНСЫЗЛАНУ** *ф. күч. гади с.* 1) Артык юмартлану, кирәгеннән артык юмартлык күрсәтү. *Болай да юмарт күңелле Мөнирҗан, бераз кәгеп тә алса, бөтенләй ыштансызлана.* Н.Әхмәдиев. *Кризис вакытында ыштансызланырга һич кирәкми, минемчә.* Татарстан яшьләре

2) Җитди уйлап эш итмәү, җиңел акыллылык күрсәтү

**Ыштансызланып йөрү** Һәрвакыт, бөтен җирдә ыштансызлык күрсәтү. *Алай ярамый, һәркем алдында ачылып, ыштансызланып йөрергә ярамый. Башың Себер китәр, Алла сакласын!* А.Расих

**ЫШТЫ́Н-ПЫШТЫН** *рәв. сөйл.* 1) Ашык-пошык, бөтен таләпләрне дә үтәмичә, теләр-теләмәс кенә, аннан-моннан. *Кирәк – арба яса, кирәк – сука яса, җитәр-җитмәс, ыштын-пыштын эшләсәң, арбаңны яки сукаңны көн саен бер җирен төзәтми булмассың.* К.Насыйри

2) *күч.* Көч-хәл белән, ничек кирәк алай. *Хәзер ыштын-пыштын гына йодрык белән суксаң [да] таралачак өйалды ишегең ачарга кирәк иде.* Н.Гыйматдинова

**ЫШТЫР** *и. сөйл.* 1) Чабата кигәндә аякка һәм балтырга урый торган киндер яки башка шундый тупас тукыма кисәге. *Улы аягына ыштыр ураганчы, әтисе урманга җиткән.* Мәкаль. *[Мөхтинең] Битен коңгырт сакал-мыек баскан, аягында ыштыр белән чабата, өстендә кулдан суккан ашъяулык төсле кызыллы-зәңгәрле шакмаклы күлмәк.* Г.Бәширов

2) *күч.* Чиктән тыш оятсыз кеше. – *Япун биргән мәчет акчасына син дүәрис төзеп ятасың бит, үзең[не] кара, ыштыр!* В.Имамов

◊ **Ыштыр (каплаган, япкан) бит** *к.* **ыштыр** (*2 мәгъ.*). *Әй Нургаян, бу ыштыр бит Зөлфәт киленең өйдә юкта да сезгә кереп йөримени?* А.Гыйләҗев

**ЫШТЫРЛЫ** *с.* Ыштыр ураган, ыштыры булган. *[Безгә дигән обмундирование] Өскә гимнастёрка, галифе чалбар, аякка ыштырлы ботинка, билгә брезент каеш.* Казан утлары

**ЫШТЫРЛЫ́-ЧАБАТАЛЫ** *с.* Гади, надан, тупас (авыл кешесе тур.). *Ә бу китапчык безнең күрше Берёзовка кешеләре ничек сөйләшсә, нәкъ шундый тел белән, нәкъ шундый ыштырлы-чабаталы, кайры тунлы, чикмәнле авыл мужиклары хакында язылган иде.* Г.Бәширов

**ЫШТЫ́Р-ШЫШТЫР** *иярт.* Каты итеп ысылдап сөйләшкән тавышны белдерә. *Хәмит утырганның соңында, артта ыштыр-шыштыр тавышлар чыкты.* Г.Исхакый

**ЫШЫК** *и.* **1.** 1) Берәр нәрсәнең артында, астында урнашкан, капланган, җил-яңгырдан, башка куркынычлардан сакланырлык урын. *Монда [каланчада] хәзер ышык, өстән бик чылатып тормаса, төн кунарга да була иде.* А.Тимергалин. *Каршы искән юл җиле йөзгә туры бәрелмәсен өчен, әрҗәнең алгы өлешенә брезент ышык куелган.* К.Кәримов

2) диал. Күләгә. – *Әйдә, әнә теге ялгыз карама янына барып җитәбез дә, шуның ышыгына утырып, бераз ял итәбез!* В.Нуруллин

3) *күч.* Тыныч, аулак, беркем борчымый торган урын. *Бу агачлар янына килеп, кыргый хайваннар, киек-җәнлекләр ышык һәм ризык тапкан, кошлар оя корган, бала чыгарган, күкне иңләр өчен, көч җыйган...* Г.Гыйльманов

4) *күч.* Кемнеңдер яклавы, химаясе; ярдәм. *Җүкәтауга, Габбас ышыгына, энекәше куышына кереп качкан.* В.Имамов. *Баласы ата баласы, үзе ир хатыны булып, ире күләгәсендә, аның ышыгында яшәде.* Г.Бәйрәмова

**2.** *с. мәгъ.* Ышыгы булган, ышык булып хезмәт иткән. Тарлавыкны *бер-*

*тында узабыз да, теге якка чыккач, бер ышык почмак табып, палатка куярбыз.* А.Хәсәнов. *Дөмәй буенда, таллар куенында, Ятлар күзеннән ышык урында... Яшертен генә, яшеренеп кенә, Синме сөйләдең сөю турында?..* К.Булатова

◊ **Ышык бирү** 1) Һәр яктан ышыклау; 2) Ярдәм итү, яклавына алу. *Бәхетсезлек безне бергә җыйды, Ризык, ышык бирде туган ил.* Р.Шәрипов. **Ышыкка алу** *к.* **ышык бирү**. **Ышык табу** Сыенып урын, яклаучы табу. *Парижда ул [Йосыф Акчура] Әбделхәмит II нең эзәрлекләвеннән ышык тапкан яшь төрекләр белән тыгыз элемтәдә тора.* М.Хәсәнов. **Ышыкта яшәү** Тыныч, борчу-мәшәкатьсез яшәү. *Бала артыннан бала алып кайтып, иргә чыкканнан бирле бер җирдә дә эшләмичә, Мирхафизы канаты астында, ышыкта яшәгән хатын, дүрт баласы белән ятим калгач, язмышына да, Ходайга да үпкәләде.* Р.Хәбибуллина

**ЫШЫКЛАГЫЧ** *и.* Саклау җайланмасы. *Монысында сихерле бер түгәрәк килеп чыга: карлы басу болай да карлы инде, бездәйләргә анда эш юк, ә дөм такыр басуда көрәкләр белән өеп ышыклагыч ясарлык кар табып булмый.* Татарстан яшьләре

**ЫШЫКЛАМА** *и.* 1) Нәрсәдән дә булса ышыклану урыны

2) *хәрби* Кемне яки нәрсәне дә булса саклау бурычы йөкләтелгән хәрби часть, кораллы отряд; *русчасы:* **прикрытие**

**ЫШЫКЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **ышыклау**. *Ике яктан да сөзәк таулар белән ышыкланган авыл кичке талгынлыкка чума.* Казан утлары

2) Ышык урынга керү, берәр нәрсәнең артына, астына посып саклану. *Алар Зәйнең Сарман ягына чыга торган очында, җилдән ышыкланып, кабык түбәле өйгә сырышып басып калдылар.* А.Гыйләҗев. *Якын-тирәдә бер ышыкланыр төш тә булмаганга, мин, яшеннәргә уралып, абына-сөртенә, гел алга бардым.* Р.Зәйдулла

3) Нәрсәнең дә булса артына посу, яшеренү, качу. *Чия куаклары артында, коймага ышыкланып, ике хатын-кыз аның җырын тыңлый.* Д.Каюмова

4) *күч.* Кемнең дә булса яклавына, химаясенә таяну, сыену; дәрәҗәсенә, яклавына ышану. *Гафифә апа юкка гына болгатып маташа. Элекке шикелле Солтангәрәйнең аркасына ышыкланыр чакмыни?* Г.Бәширов. *Алтынбәк, үзенә кияү тиеш Иштәк бәк аркасына ышыкланып, Талкас күле ярында качып яткан иде.* В.Имамов

**Ышыклана башлау** Ышыкланырга керешү. *Бүре хәзер авыр йөгерсә дә, куып тотып булмый иде әле, ул агачларга ышыклана башлады, юлын урап-болгатып эз яздырырга тырышты.* З.Мурсиев

**Ышыкланып тору** Бераз, вакытлыча ышыклану. *Фәнисә, бер җирдә дә ышыкланып тормыйча, ашыкмыйча гына өенә таба атлады.* Ә.Сафиуллин

**ЫШЫКЛА́У** *ф.* 1) Җил, яңгыр, салкын кебек тышкы тәэсирләрдән киртәләп, томалап саклау. *Бакчасына күпмедер күңел биргән хуҗалар моны яхшы белә, кырау килгән көннәрдә түтәлләрен ышыклап каплый.* М.Маликова. *Явымда ышыклый, эсседә сусынны баса, күләгәсе, тәмле суы белән хәл кертә торган куышта күрше-күлән, дус-иш күңел бушатып утырырга да мөмкин.* Т.Әйди

2) Күләгәләү, кояшның туры нурларыннан саклау. *Күзләрен кояштан ышыклар өчен, бер кулын кашлары өстенә куеп, лабаз ягына карана иде.* Ш.Камал

3) Үзе белән каплау, күрсәтмәү. *Ә өйнең иң түр почмагында, искечә язулы рамнарны ышыклап, таныш читлек эленгән.* Г.Гыйльманов. *Сал-Сал батыр йөзе Бөкре Карун белән әмир Әбүгали чатырлары корылган калкулыкны ышыклап баскан иде.* В.Имамов

4) Ярдәм итү, яклау, саклау. *Карелиядәге Киров тимерьюлы өчен барган алышта кызылармияче Камилҗан Адыевка тимерчыбыклы киртәне кисеп чыгарга дигән приказ бирелә, аны Чиләбе һәм Курган өлкәсеннән булган ике яудашы ышыклый.* Кызыл таң

**Ышыклап кую** Тиз генә ышыклау, ышыкланган хәлгә китерү. *Малайлар янына җитүгә, Фатыйма кулындагы япма белән бәпкәләрне яңгырдан ышыклап куя.* М.Кәбиров

**Ышыклап тору** Һәрвакыт, гел ышыклау. *Утрауда җылы климат хөкем сөргән, төньяктагы таулар салкын җилләрдән ышыклап торганнар.* А.Тимергалин

**Ышыклый төшү** Тагын да бераз ышыклау

**ЫШЫКЛЫК** *и.* 1) Ышык урын. *Алар, бүтән ләм-мим сөйләшмичә, урман ышыклыгыннан бераз бардылар.* Казан утлары. *Югыйсә урманда ышыклык күп, корылык ул кадәр борчымаска да тиеш кебек.* Ватаным Татарстан

2) *күч.* Ярдәм, таяныч. *Төннәр буена сөйләшеп, киңәшеп туя алмау, кирәк чакта бер-береңә ышыклык бирә алу, арка терәге була белү кала торгандыр.* Т.Галиуллин

3) *күч.* Йогынтылы, зур дәрәҗәле кешеләр тирәсе. *Һәрхәлдә, Крупп кебек магнатлар ышыклыгында Гросманнарга да, Паульләргә дә урын әзер.* Н.Дәүли

**ЫШЫЛДАТУ** *ф. сөйл.* Ышылдаган тавыш чыгару. *Каргалар канатлары, койрыклары белән иртәнге салкын һаваны ышылдатып ярып, кинәт аска төшәләр.* Казан утлары

**ЫШЫЛДА́У** *ф. к.* **ысылдау** (*1, 2 мәгъ.*). *Җаны бимазаланудан көлсу, кипшенгән иреннәрен тибрәтте, тешсез авызыннан тавышы ышылдап чыкты.* Н.Хәсәнов. – *Ә сызгыра беләсеңме? – ике бармагын авызына тыгып ышылдап күрсәтте Алия. – Менә болай.* Казан утлары

**ЫШЫ́Н-ПЫШЫН** *рәв. сөйл.* **1.** Яшертен, пышылдап колакка гына. *Халык күтәрелмичә, сугыш бетмәс, ахры, дигән сүзләр баштарак ышынпышын, соңрак ачыктан-ачык ишетелә башлый.* Казан утлары

**2.** *с. мәгъ.* Яшерен, сер итеп әйтелгән; халык телендә йөргән. *Бу турыда авыл халкы арасында да ышын-пышын сүзләр йөрүе Иргали өчен сер түгел иде.* М.Хәсәнов

**ЫШЫ́Т-ЫШЫТ** *ы.* **1.** Кош-корт, вак җәнлекләрне куганда, куркытып әйтелә. *Әби табагач алды һәм [күселәрне куарга дип] өстәл астына иелде: – Ышытышыт, нәләт суккырлары.* Г.Кутуй

**2.** *ирт.* Пычкы белән агач кискәндә чыккан тавышны белдерә

**Ы-Ы** *ы.* **1.** Кирәкле сүзне таба алмый торганда әйтелә. *Ы-ы... ни... хуҗам, ул әйтте: – Очлы тау итәгендәге Зәңгәр күл буенда, Ялгыз кыя янында, – диде.* Н.Фәттах. – *Гафу итегез, ы-ы, беләсезме, теге, ни, ыһым, миңа, ни, Айчибәрнең, теге ни, адресы кирәк иде, – дип, авыз эченнән ботка пешердем.* Н.Әхмәдиев

**2.** *хәб. сүз мәгъ. сөйл. к.* **әйе** *(1 мәгъ.)*. – *Ә бит ул чакта сыер саткан акчасын барыбер алып кайтмаганые ул! – диде шунда моңарчы гел ы-ы, ы-ы дип, Фатыйх абзыйның сүзен җөпләп утырган Хафиз карт.* В.Нуруллин

**Ы́Э-МЫЭ** *ы. к.* **ык-мык**

**ЫЭ-МЫ́Э ИТҮ** *ф. к.* **ык-мык итү**. *Шәкерт «ыэ-мыэ» итеп урынында утырып калмакчы иде, ләкин икенче тапкыр күтәрелә башлаган таяк аны тиз генә бүлмәне ташлап чыгып китәргә мәҗбүр итте.* Ә.Фәйзи

**ЫЭ-МЫ́Э КИЛҮ** *ф. к.* **ык-мык итү**

# Э

**Э** *ы.* 1) Әңгәмәдәшенең фикере белән тулысынча килешеп бетмәүне, икеләнүне, ышанмауны, каршы килүне, үзенең нindидер башка фикере булуын белдерә. *Э-э, ашатмас биш тапкыр.* Г.Гобәй. *Э… шушы көннәрдә бугай.* Карчыга

2) Каушаудан, фикер онытылудан кирәкле сүзнең әле тәмамланмавын белдергәндә әйтелә. *Фәйзерахман малае ул э… э… алма агачыннан ерак төшми, ди торган иде ич әти мәрхүм.* А.Әхмәт. *Мин сезнең… чыгып китүегездән… э-э… югалуыгыздан куркам.* Х.Ширмән

**ЭБЕН** *и. гр. бот.* 1) Эбенчалар семьялыгына караган, Һиндстан һәм Шри-Ланкада таралган, кыйммәтле кара үзагачлы тропик агач; кара агач

2) Эбенчалар семьялыгына караган кайбер тропик агачлардан алынган, иң кыйммәтле саналган, үтә каты, кара яки кара буйлы үзагачның гомуми атамасы

**ЭБЕ́НЧАЛАР** *и. күпл. бот.* Икеөлешле үсемлекләр классыннан хөрмә, кара сапота, маболо кебек агачларны берләштергән семьялык

**ЭБИ́-ЧЕБИ** *җый. и.* Ыбыр-чыбыр. *Клуб янында эби-чеби җыелган иде.* Б.Камалов

**ЭБОНИТ** *и. гр.* **1.** *махс.* Гадәттә кара төстәге, утыз проценты күкерттән торган, кислота, селте тәэсиренә чыдам, электр үткәрми торган, каты, ялтыравыклы материал; вулканлаштырылган каучук. *Ул [Юлдаш] аннан эбонит таягы, акбур кисәге, нindидер пробиркалар чыгарды.* Ә.Ибраһимов. *Резин – каучукны вулканлаштыру нәтиҗәсендә хасил булган эластик материал. Вулканлаштыру дәрәҗәсе буенча йомшак, ярымкаты һәм каты (эбонит) төрләргә бүленә.* Төзү материаллары. *«Sony» маркалы япон телевизорларының кайбер микросхемаларын ясаганда эбонит кулланыла.* Юлдаш

**2.** *с. мәгъ.* Шул материалдан ясалган, составында шул материал булган. *Көзнең кыска көнен караңгы алганда, Кәшфи өенең түрендә, тегү машинасы куелган зур өстәлдә, кара эбонит телефон аппараты тора --- иде.* М.Мәһдиев. *--- елмаюын сакларга тырышып, криминалистика өлкәсендәге яңа техник казанышлар турындагы плакаттан аерылгач, кулындагы эбонит таягын Ансарга төбәде.* К.Кәримов

**ЭВАК** *и. рус сөйл. к.* **эвакуант**. *Квартирага Ленинград эвакларын куйдылар.* Х.Камалов

**ЭВАКО-** *рус* Кушма сүзләрдә «эвакуация белән бәйле» мәгънәсендәге беренче кисәк (мәс., *эвакогоспиталь, эвакопункт* һ.б.)

**ЭВАКОГО́СПИТАЛЬ** *и. рус* Сугыш барган җирләрдән яки төрле табигать афәтләре вакытында эвакуацияләнеп килгән яралыларны һәм авыруларны дәвалый торган госпиталь; эвакуация госпитале. *Мөхәммәт Уразаев һич котыла алмады шушы К. шәһәре читенә урнашкан эвакогоспитальдән.* Я.Зәнкиев. *[Хөсния] язу-сызудан бизгән бармакларын көчләп эшкә җикте дә яза башлады: «Эвакогоспитальнең икенче корпустагы бүлек начальнигы Анна Захаровага…»* Р.Ишморатова

**ЭВАКОПУНКТ** *и. рус* Сугыш барган җирләрдән, төрле табигать афәтләре вакытында яралыларны һәм авыруларны эвакуацияләү һәм дәвалау максатларында төзелгән дәвалау һәм эвакуация-транспорт учреждениеләренең бер үзәктән идарә ителгән берләшмәсе; эвакуация пункты. *Немецлар Мәскәү янына килеп җиттеләр. Хәзерге Татар дәүләт академия театры эвакопунктка әйләндерелде.* Т.Гыйззәт. *Ә япа-ялгыз калган балаларны эвакопунктка җыеп алганнар ---.* Ә.Еники. *Яралыларны табу һәм эвакопунктка ташу өчен, мендәрләр салынган кул чаналары хәстәрләү --- белән матавыкландылар.* Р.Газизов

**ЭВАКУАНТ** *и. рус* Эвакуациядәге кеше, эвакуацияләнгән кеше. *Эвакуантларны мәктәп бинасына урнаштыру*

**ЭВАКУА́ТОР** *и. рус* 1) Эвакуация эшләре белән шөгыльләнүче, эвакуацияләүче кеше. *Эвакуатор башта Гаҗиләә җиңги белән бәхәскә керде. Билетка заказ бирелгән, срогын үзгәртеп булмый, диде.* М.Мәһдиев

2) Юл-транспорт фаҗигасында зур зыян күргән, юл йөрү кагыйдәләрен бозган транспорт чараларын вакытлыча тоту урыннарына алып китә торган машина. *Егетләр, сезнең ярдәм кирәк миңа бу чибәр туташка. Карагыз машинасын. Әгәр рәтләрлек булмаса, эвакуатор чакыртып, автосервиска илтегез.* Ф.Яруллин. *Кич белән капка төбенә эвакуатор туктады.* Н.Гыйматдинова

**ЭВАКУАЦИОН** *с.* Эвакуациягә бәйләнешле, шуңа мөнәсәбәтле. *Эвакуацион чаралар күрүче дошман чигенергә әзерләнә.* Д.Сирай. *Эвакуацион комиссия*

**ЭВАКУА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Дошман һөҗүме яки табигый афәт янаганда, берәр зур төзелеш өчен территорияне бушату ихтыяҗы булганда һ.б.ш. җитди сәбәпләр белән халыкны, милек, предприятие, учреждениеләрне оешкан төстә башка урынга күчерү эше. *Авыл халкы берсүзсез эвакуациягә әзерләнә башлады.* Җ.Шакиров. *Җир тетрәгән районнан балаларны эвакуациягә әзерләү*

2) Сугыш хәрәкәтләре барган территориядән яралыларны, әсирләрне, хәрби милекне һ.б.ш.ны планлы рәвештә тылга күчерү эше. *Беренче чиратта авыр яралыларны эвакуация тәртибендә ерак тылга күчерү турында боерык килде.* Х.Камалов. *Чиккән сөлгеләрне, милли тастымалларны Төмән шәһәренә эвакуациягә агылган марҗалар, яһүди апалар бик теләп алалар иде.* Я.Зәнкиев

3) Эвакуация (*1–2 мәгъ.*) нәтиҗәсендә килеп урнашкан урын һәм шунда узган вакыт. *Сугыштан соң эвакуациядән туган җирләренә кире кайтты. Эвакуациядә яшәү шартлары искиткеч авыр иде.* Г.Гобәй

4) Берәр гадәттән тыш куркыныч хәлдә бина, зур корылма һ.б.ш.дан чыгу. *Кайбер объектларда эвакуация юллары капланган, анда чүп-чар тутырылган.* Мәйдан. *Видеокүзәтү юк, эвакуация схемасы беркайда да урнаштырылмаган.* Идел таңнары

**ЭВАКУА́ЦИЯЛӘНҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **эвакуацияләү**. *Ул эвакуацияләнә алмыйча калган. Финнар аны, бүтәннәр белән бергә, чәнечкеле тимерчыбык эченә – лагерьга кертеп япканнар.* Г.Әпсәләмов. *Беләм, курсташларым да хәлемне аңлыйлар, бигрәк тә Киевтан эвакуацияләнеп килгәннәр.* Л.Ихсанова. *Лениногорск районының берничә авы-*

*лын су баскан. Кәркәле, Иске Писмән, Сугышлы авылларында 21 йорт су эчендә калган, 16 кеше эвакуацияләнгән.* Ирек мәйданы

2) Гомумән бер урыннан икенче урынга күчерелү; тышка чыгарылу. *Юан эчәкнең вазифасы – үзенә килеп җиткән тизәкне саклау белән беррәттән, аның эвакуацияләнүен дә тәэмин итү.* Юлдаш

**Эвакуацияләнә башлау** Эвакуацияләнергә тотыну. *Шәһәр халкы ашыгыч рәвештә эвакуацияләнә башлый.* Кызыл таң

**Эвакуацияләнеп бетү** Барысы да эвакуацияләнү. *Бар да көнчыгышка эвакуацияләнеп бетте.* Г.Гобәй. *Авыл халкының шактый өлеше эвакуацияләнеп беткән иде инде.* Казан утлары

**Эвакуацияләнеп тору** Хәзер, сөйләү моментында эвакуацияләнү; һәрвакыт, гел эвакуацияләнү

**ЭВАКУА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* 1) Эвакуация үткәрү, халыкны, яралыларны һ.б. куркыныч булмаган урынга күчерү. *Сугыш башлангач, аларны ашыгыч рәвештә Караганда өлкәсенә эвакуацияլиләр.* С.Ибраһимова. *Дошман шәһәр капкасында. Халыкны эвакуацияլиләр, ләкин трактор заводы эшли.* Казан утлары. *Башкортстан белән чиктәш Оренбург өлкәсендә торак пункты тоташы белән диярлек янып беткән – Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы кешеләрне эвакуацияли.* Мәйдан

2) Берәр матдәдән, составтан нәрсәне дә булса аерып чыгару. *Лаборатория шартларында эремәдән аммиакны эвакуацияләү*

**Эвакуацияләп бетерү** Барысын да эвакуацияләү; эвакуация эшен тәгәлләү. *Моннан 25 ел элек Чернобыль АЭСы шартлагач, анда яшәүче халыкны эвакуацияләп бетергәннәр иде.* Шәһри Казан. *АЭСка якын булган җирлектә яшәгән барлык кешене тиз арада эвакуацияләп бетергәннәр.* Ирек мәйданы

**Эвакуацияли башлау** Эвакуацияләргә керешү. *Икенче апрельдә Хәрби-политик үзәккә Бухенвальдны эвакуацияли башлау турында Берлиннан боерык килгәнлеге мәгълүм булды.* Г.Әпсәләмов. *Сәгать төнге икедә кунакханәдән аэропортка кузгалдык, ә дүрттә ял итүчеләрне эвакуацияли башлаганнар.* Шәһри Казан

**ЭВАКУА́ЦИЯЛӘҮЧЕ** *и. к.* **эвакуатор** (*1 мәгъ.*). *Төзәтмәләр шофёрларга да, эвакуацияләүчеләргә дә кагыла.* Якты юл

**ЭВДЕМОНИЗМ** *и. гр. филос.* Кешенең яшәү максаты – шәхси бәхеткә омтылу, дип өйрәткән тәгълимат. *Эвдемонизм тарафдары*

**ЭВЕН** *и.* Тунгус-манчьжур телләренең берсендә сөйләшкән, күпчелеге православие динен тоткан, Охот диңгезе ярларында һәм Саха-Якутиянең төньяк районнарында яшәгән халык атамасы һәм шул халыкның бер вәкиле. *Коля-Николаша, дип йөртәм мин аны. Эвен егете.* Н.Мусин. *Якутларда, эвеннарда аюга табыну хөкем сөрә икән.* Ә.Ибраһимов

**ЭВЕНК** *и.* Тунгус-манчьжур телләренең берсендә сөйләшкән, Россиянең Эвенк милли округында һәм Көнчыгыш Себердән алып Тын океанга кадәр территориядә яшәүче халык атамасы һәм шул халыкның бер вәкиле. *Эвенклар балык тоту һәм аучылык белән шөгыльләнәләр. Якутлар – якутча, эвеннар, эвенклар, юкагирлар үзләренчә кычкыра, кулларын, бүрекләрен болгый.* Н.Мусин. *Йомышыгыз төшсә, аңа [Михай-Баянай дигән аучыга] мөрәҗәгать итеп карагыз. Хатыны – эвенк.* М.Хәсәнов

**ЭВЕ́НКЧА** *рәв.* **1.** 1) Эвенк телендә. *Соңрак «баянай» дигән сүзнең мәгънәсен дә белдем. Эвенкча «сунарчылык алласы» дигән сүз икән.* М.Хәсәнов. *Эвенкча язу*

2) Эвенк халкындагыча. *Эвенкча балык ашлары әзерләү*

**2.** *с. мәгъ.* 1) Эвенк телендәге. *Туйда аңардан эвенкча җыр җырлаттылар*

2) Эвенк халкына караган, шуңа хас булганча. *Эвенкча бәйрәм итү*

**3.** *и. мәгъ.* Эвенк теле. *Эвенкчасы бик яхшы*

**ЭВЕ́НЧА** *рәв.* **1.** 1) Эвен телендә. *Катяның чын исеме Кинголо икән, эвенча «җәй» дигәнне аңлата, димәк, дөньяга җәй туган тайга кызы.* С.Шәрипов. *Эвенча сөйләшү. Эвенча уку*

2) Эвен халкындагыча. *Эвенча киенү*

**2.** *с. мәгъ.* 1) Эвен телендәге. *Эвенча китап уку*

2) Эвен халкына караган, шуңа хас булганча

**3.** *и. мәгъ.* Эвен теле. *Малайның эвенчасы чамалы икән*

**ЭВКАЛИПТ** *и. гр. бот.* Миртчалар семьялыгыннан Австралиянең тропик һәм субтропикларында таралган, кайрысы кыйммәтле төзелеш материалы булган, бик тиз үсә торган мәңгеяшел агач. *Әле кичә генә игътибар иткән идем: Гагра урамында тезелеп утырган йөзьяшәр эвкалиптлар иске кабыкларыннан арына башлаганнар ---.* М.Мәһдиев. *Австралия саванналарында зур эвкалиптлар --- өстенлек ала.* Физик география

**ЭВКО́ММИЯ** *и. лат. бот.* Эвкоммиячәләр семьялыгыннан яфраклары, кайрысы, тамырлары гутка бай (гуттаперча әзерләүдә кулланыла) көньяк агачы. *Карама яфраклы эвкоммия*

**ЭВОЛЮ́ТА** *и. лат. мат.* Җәелмәле яссы кәкре. *Эволютаның координаталарын табу*

**ЭВОЛЮЦИОН** *с. кит.* 1) Эволюция хәлендәге, үсештәге, эволюция булып торган. *Тел вә дин ягыннан үзара кардәш төркемнәр тәшкил иткән халыкларда да үзенчәлекле зур эволюцион үзгәрешләр туды ---.* Р.Фәйзуллин. *Р.Фәхреддин --- эволюцион үсеш, цивилизация казанышларын ватмау-җимермәү, явызлыкны, кан коюларны булдырмау ягында иде.* М.Хәсәнов

2) Үсеш, эволюция теориясен тикшергән; шуңа нигезләнгән; шуны өйрәтә торган; шуңа караган. *Дарвин – табигый сайланыш юлы белән хайваннарның һәм үсемлекләрнең төрләре барлыкка килү турындагы эволюцион тәгълиматка нигез салучы.* Һ.Такташ. *Әхмәров Нияз – невропатолог, генетик, медицина фәннәре докторы. --- Рефлексотерапия, Шәрык медицинасы, эволюцион медицина, клиник генетика, бионика, психология һәм философия буенча хезмәтләре бар.* А.Тимергалин

3) *хәрби* Кораблар һәм гаскәрләр сафларының үзгәрүенә, башкача төркемләнешенә бәйле. *Эволюцион өйрәнүләр*

**ЭВОЛЮЦИОНИЗМ** *и. лат. кит.* 1) Барлык нәрсә өзлексез үзгәреп, эволюция кичереп тора, дип раслаган тәгълимат. *Постклассик булмаган этапка эволюционизм, тере материя белән тере булмаган материя арасындагы бәйләнешләрне глобаль эволюция принциплары җирлегендә карау хас.* К.Гыйззәтов. *Бу дөньяның барлыкка килүе мәсьәләсендә хәзерге заман фәне ике капма-каршы фикердә тора: креационлык --- һәм эволюционизм.* Юлдаш

2) Җир йөзендәге барлык нәрсә, шул исәптән җәмгыятьнең үсеш процессындагы революцион үзгәрешләрне, кискен сикерешләр булу мөмкинлеген һәм аларның әһәмиятен танымаган фәлсәфи тәгълимат. *Эволюционизм тәгълиматларына нигезләнгән хезмәт*

**ЭВОЛЮЦИОНИСТ** *и. рус кит.* Эволюционизм тарафдары. *Билгеле булганча, болар барысы да – Дарвинга кадәрге чор эволюционистларын, шул исәптән Ламаркны да, аптыраштта калдырган сораулар.* Дарвинизм һәм дин

**ЭВОЛЮЦИОНИ́СТИК** *с. кит.* Эволюционизмга мөнәсәбәтле, эволюционизмга нигезләнгән, эволюционистларга хас. *Эволюционистик карашлар*

**ЭВОЛЮ́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Кемнең яки нәрсәнең дә булса туктаусыз үсү, үзгәрү процессы, прогресс, гомумән үсеш. *Шундый үзгәрешләр һәм эволюция булмаса, гомер бик соры төстә тамаша ителер иде.* Б.Урманче. *Эмоция – хайваннар дөньясы эволюциясендә һәм психиканың филогенезында алдарак барлыкка килгән психик чагылыш формасы.* Кызыклы психология

2) *филос.* Табигатьнең яки җәмгыятьнең сан-микъдар үзгәрешләрен сыйфат үзгәрешләренә китерә торган эзлекле үсеш формасы

3) *хәрби махс.* Хәрби корабльләрнең һәм гаскәрләрнең сафлары үзгәрүенә, башкача төркемләнешенә китерә торган хәрәкәтләр; манёврлар. *Диңгез эволюцияләре*

**Э́ВРИКА** *ы. гр. кит.* Берәр нәрсәне чишү, уйлап табу яки башка берәр яхшы фикер килү шатлыгыннан әйтелә торган сүз. *Кызыл хачка күзе төшкәч, Әхәт баскан урынында сикереп куйды: «Таптым! Эврика!»* А.Гыйләҗев. *Урра-а! Эврика! Менә икән бит ул языласак кыйссам!* Ж.Дәрзаман

**ЭВРИ́СТИК** *с.* Яңа гыйлем алу, моңа кадәр билгеле булмаган закончалыкларны, үзенчәлекләрне һ.б.ш. табу мөмкинлеге бирә торган. *Иҗади фикерләү эвристик алымнар куллануны да сорый.* Фән һәм тел. *Бу эвристик ысулны (кагыйдәне ятлатасы түгел, киресенчә, укучының үзеннән эзләтеп таптырасы) Ф.И.Буслаев, К.Д. Ушинскийлар тәкъдим иткән булган.* Фәнни Татарстан

**ЭВРИ́СТИКА** *и. гр. кит.* 1) Борынгы Грециядә ярдәмче сораулар бирү юлы белән укыту системасы

2) Теоретик тикшеренүләрнең һәм хакыйкатьне эзләүнең логик алымнар һәм методик кагыйдәләр җыелмасы

3) Иҗат эшчәнлеген өйрәнә торган фән. *Алар, үзләре дә сизмичә, бер теориядән икенчесенә, бер фараздан икенче фаразга күчәләр, ләкин әңгәмәнең үзәге һаман бер: эвристика, иҗади фикер эшчәнлеге...* А.Тимергалин

4) Укучыларның тапкырлыгын һәм активлыгын үстерү максаты белән ярдәмче сораулар бирүгә нигезләнгән укыту методикасы. *П.А.Шмаков сүзендә торды: 6 нчы сыйныфта профильле укытуга әзерлекне тәэмин итте, факультатив яки түгәрәк буларак, эвристика, информатика, физика кебек фәннәр укытыла башлады ---.* Шәһри Казан

**ЭВРИ́СТИКЛЫК** *и.* Яңа гыйлем алуга, моңа кадәр билгеле булмаган закончалыкларны, үзенчәлекләрне табуга сәләтлелек. *Эвристиклык – күзгә күренми торганны күрү сәләте*

**ЭВФЕМИЗМ** *и. гр. лингв.* Турыдантуры әйтүе уңайсыз, дорфа яки әдәпсез килеп чыгу ихтималы булган сүзләрне алыштыра торган сүз яки тәгъбир (мәс., *алдама* урынына *борчак сипмә* дип әйтү). --- *аның сүзләре хатыннар телендә эвфемизмнарга әйләнгәннәр.* И.Абдуллин. *Авылларында Күсе кушаматлы кеше бар, шул кешенең исемен дә эвфемизм итеп сөйләшү күзәтелә: «Абзарга Ракип кергән».* Ф.Сафиуллина

**ЭВФЕМИ́СТИК** *с. лингв.* Эвфемизм булып торган, эвфемизмнан гыйбарәт; шуңа караган. *Бу алымны эллиптик, риторик, эвфемистик яки мәкальне җыйнакландыру йөзеннән эшләнә торган кыскартулар белән буташтырмаска кирәк.* И.Бәширова. *Татар телендә эвфемистик антонимнар аерым урын билән тора.* Татар лексикологиясе

**ЭВФО́НИК** *с. к.* **эвфонияле**. *Бу әсәрдә --- авылның реалистик картиналарын --- бирергә омтылу һәм шуның үзенә күрә бер формасы да табылу (орчык тавышына иярү, эвфоник алымнар) [сизелә].* Н.Исәнбәт. *Т.Ковальский, үзенең фикеренә дәлил итеп, керәшен татарлары җырларында рифманың эвфоник охшашлыкка караганда сурәтне яки эчтәлекне ачкан сүзләрнең кабатлануына нигезләнүен саный ---.* Н.Юзиев

**ЭВФОНИ́Я** *и. гр. әд.* Матур әдәбиятта, аеруча поэзиядә, авазларның тигез, матур, гармонияле яңгырашы; аһәңле яңгыраш. *Эвфония буенча, бертөрле аваз юк, бер төркемнән булган охшаш авазлар гына бар.* Х.Туфан. *Тезмә кушма җөмләләрнең структурсемантик бәйләнешен тәгъбир итүдә, --- эвфония әһәмиятле роль уйный.* Г.Нәбиуллина. *Татар антропонимиясе үсешенең яңа этабында эвфония факторы исем бирү мотивларын билгеләүдә мөһим булып тора.* Г.Шәйхиева

**ЭВФОНИ́ЯЛЕ** *с.* Эвфониягә нигезләнгән, үзендә эвфония булган. *Эвфонияле яңгыраш*

**ЭВФУИЗМ** *и. гр. әд.* Сөйләмдә, матур әдәбиятта артык бизәкле, күтәренке, кабарынкы стиль

**ЭГАЛИТАР** *с.* Һәр кешегә үзенә тиң дип караган, һәр кеше тигез дип раслаган; тигезли торган, тигезләү принцибына нигезләнгән. *Эгалитар режим. Эгалитар система. Эгалитар утопия*

**ЭГАЛИТАРИЗМ** *и. фр.* Җәмгыятьтә байлык һәм керемне үзара тигез бүлү принцибы; шуңа нигезләнгән сәясәт. *Большевикларның фанат эгалитаризмы колларча эшләү системасын тудырды.* Юлдаш. *Эгалитаризм тарафдары*

**ЭГАЛИТАРИСТ** *и. рус* Эгалитаризм тарафдары

**ЭГАЛИТАРЛЫК** *и. фр.* Тигез хокуклылык, тигезлек. *Гаилә мөнәсәбәтләрендә эгалитарлык*

**ЭГИ́ДА** *и. гр.* 1) Борынгы грек мифологиясендә Зевс (сирәгрәк Афинаның) калканы, аның химаясен яки ярсуын белдергән символ

2) Берәр оешма, берләшмә һ.б.ш.га карау, шуның яклавында, җитәкчелегендә, химаясендә булу, эшләү. *Һәр тармакөлкәнең үзенең максаты, сәясәте, шул нисбәттән үзенең идеологик-тәрбия органы булган. Әйтик, балалар һәм үсмерләр әдәбияты элегрәк – комсомол, соңрак яшьләрнеке дип йөртелгән министрлык эгидасында булган ---.* Р.Фәйзуллин. *Мөселман археологиясе проблемаларын тикшерү кысаларында Казанда Татарстан Фәннәр академиясе эгидасы астында илдә беренче тапкыр Россия һәм БДБ илләре мөселман археологиясе конгрессы үткәрелде.* Фәнни Татарстан

**ЭГО** *и. лат. филос.* Психоанализ теориясе буенча, шәхеснең аның чынбарлыкка карата үзенең урынын билгеләгән, «мин» дип кабул ителә торган өлеше. *Безнең чикләнгән бәләкәй эго (эгоист – үз-үзен яратучы), асылда бөтен барлыгыбыз шул дип ялгышабыз.* Сөембикә

**ЭГОИЗМ** *и. фр.* Кеше характерындагы үзен генә ярату, үзенең шәхси мәнфәгатьләрен башка кешенекеннән өстен кую сыйфаты; үзен тотышында шундый гадәт. *Аңарда искелек калдыклары, эгоизм һәм башкалар бар кебек.* М.Җәлил. *Миндә малайлык эгоизмы көчле: апаны кемгәдер тапшырасы килми.* Т.Галиуллин

**ЭГОИСТ** *и. фр.* **1.** Шәхси мәнфәгатьләрен беренче планга куеп, үзен

генә кайгыртучы, үз-үзен генә яратучы кеше. *Килдековны бер дә алай мактамый торган иде ләбаса шушы кызый. Мактанчык, гөрбиян, эгоист, кына дип җибәрә торган иде.* В.Нуруллин. *Эгоист ул Гөлкәй. Үзе турында гына уйлый.* Х.Ширмән

**2.** *с. мәгъ.* Үзен, үз мәнфәгатьләрен генә кайгырта торган. *Мин, үзең әйтмешли, эгоист кеше. Эгоист кеше кактырып-суктырып сөйләгәнне яратмый.* Т.Миңнуллин. *Көйсез, назлыбикә, үз дигәнчә генә эш итәргә яраткан, башбаштак, үз-үзен генә яратучы эгоист кыз булып үсте.* Ә.Салах

**ЭГОЙСТИК** *с.* Эгоизм белән сугарылган, шуны чагылдырган. *Сабантуй җитәрлек дәрәҗәдә якты идеаллар өчен көрәшергә өйрәтә! Һәрхәлдә, вак, тар, эгоистик амбицияләр өчен көрәшергә өйрәтми ул!* И.Вәлиуллин. *Эгоистик максатлар һәм омтылышлар белән агуланмаган яшь йөрәкләр олы җанлы, көчле шәхесләрне тансыклый.* Казан утлары

**ЭГОИСТЛАНУ** *ф.* Эгоист кешегә әйләнү, эгоист булып китү. *Мин бераз гына эгоистландым.* М.Мәһдиев // Эгоистларча кылану, эгоистлык күрсәтү. *Врачлар яралының психологиясеннән чыгып эш итәләр: ярасы аның төзәлгән, ләкин ул эгоистланып, ярам авырта, дип, авыруга салынып маташа.* Х.Камалов

**ЭГОИСТЛА́РЧА** *рәв.* Эгоистларга хас булганча, үз-үзен яратучылар кебек. *Хатын-кызлар ирләр белән тигез хокуклы, дигәнне эгоистларча аңларга тырышмыйча, дөрес-туры итеп кенә уйлаганда, бүгенге дөнья гаилә дилбегәсен нык тота торган ир-атка мохтаҗлана түгелме соң?* Б.Камалов. *Бу бәләкәй савытлардан ашасаң мәңге туймассың, дип уйлап алуым булды, хуҗа кеше: «Кайгырмагыз, ризык җитәрлек, өстәвенә алар бик туклыклы», – дип, минем эгоистларча борчылуымны таратты.* Р.Сәгъди

**ЭГОИСТЛЫК** *и.* Кеше характерындагы эгоист булу, үз-үзен генә ярату сыйфаты; шундый кыланыш. *Әмма мәктәптә үк башланган мин-минлек, бөтен кешедән өстен булырга тырышу, эгоистлык чаткылары һаман дөрли барып, ялкынга әвереЛде бервакыт.* С.Поварисов. *Каян килә ялгызлык? Бәлки, кешенең эгоистлыгыннандыр?* Р.Мулланурова

**ЭГОТИЗМ** *и. лат.* Үз шәхесең, абруең турында артык югары фикердә булу күренеше, үзеңне артык югары бәяләү гадәте, үз-үзеңә гашыйклык. *Эготизм белән сугарылган автобиография*

**ЭГОЦЕНТРИЗМ** *и. лат. кит.* Көчле мин-минлек, һәрдаим үзен сиздереп торган эгоизм; индивидуализм һәм эгоизмның кискен формасы. *Моңа төп сәбәп – тәнкыйтьне газеталарның баш мәкаләләрендә, радиодан гына пропагандалап, асылда төкереп карау, үз вазифаңнан курку, карьеризм, эгоцентризм сәбәпче булуы.* И.Абдуллин. *М.Ю. Лермонтов дөньяда яшәүнең мәгънәсен таба алмаган, кешеләрнең язмышы белән уйнаган, салкын эгоцентризм корбаны булган Печоринны да үз заманының каһарманы дип тәкъдим итә.* А.Әхмәдуллин

**ЭГОЦЕ́НТРИК** I *и. рус* Эгоист, эгоцентрист. *Артистларның берсе, Н., иң талантлысы һәм иң шөһрәтлесе – боздай салкын эгоцентрик һәм циник булып чыкты.* В.Леви

**ЭГОЦЕ́НТРИК** II *с.* Эгоцентризмны чагылдырган, асылы эгоцентризмнан гыйбарәт булган, эгоцентризмга нигезләнгән. *Моның нигезендә һәр милләт вәкиленең --- үз халкын башкалардан өстенрәк күрү теләге, үз файдасын гына күздә тотуы, ягъни эгоцентрик эгоизм ята.* Т.Галиуллин. *Ләкин Мәдинәдән баш тарту аның шәхесендә эгоцентрик башлангычны алга чыгара.* Фәнни Татарстан

**ЭГОЦЕНТРИСТ** *и. рус* Үзен генә яратучы, көчле мин-минлекле, үтә эгоист кеше. *Тагын бер момент: бала – табигате белән эгоцентрист.* М.Әхмәтҗанов

**ЭГРЕТ** *и. фр.* Гадәттә кыйммәтле металлардан ботак, тәлгәш яки каурый формасында эшләнгән яисә чын каурый беркетелгән, хатын-кызның баш киеменә һәм чәченә кадап куела торган брошька охшаш бизәнү әйбере. *Эшләпәгә эгрет куйдыру*

**ЭДЕЛЬВЕЙС** *и. нем. бот.* Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан биек тау башларында үсә торган, көмештәй ак чәчәкле, куе ак җепселләр белән капланган күпьеллык үләнчел үсемлек. *Эльбрус... Андагы кыяларда эдельвейслар гына чәчәк атып утырмый.* Ә.Гаффар. *– Роза, ландыш, сирень, гладиолус, пион, эдельвейс, бегония... – Рәхмәт сезгә, җирдә утыз мең төрле чәчәк үсә, барысын да санап бетерә алмассыз.* К.Кәримов

**ЭДИКТ** *и. лат. тар.* 1) Борынгы Римда дәүләт хезмәтендәге кешенең белдерүе, боерыгы. *Претор эдикты. Каракалла эдикты*

2) *кит.* Төрле дәүләтләрдә иң югары хакимиятнең үтә мөһим указы. *Алар икесе дә Милан каласына җыенга баралар һәм 313 елда, христиан динен тыймаска, дигән җыен чыгарган эдиктка кул куялар.* М.Хәбибуллин. *Нант эдикты аркасында гугенотлар белән католиклар арасындагы сугышлар бетерелгән.* Урта гасырлар тарихы

**ЭЖЕ́КТОР** *и. фр.* 1) Эжекциядән (*1 мәгъ.*) файдалануга нигезләнгән аппарат (агымтылы насосларда, мәс., моторларда кулланыла)

2) *тех.* Ату коралында, затворны ачканда, атылган патрон гильзасын автомат рәвештә чыгарып ташлый торган механизм

3) Һава яки пар агымы җибәреп, утлы корал көпшәсе каналын дары газларыннан чистарта торган прибор

**ЭЖЕ́КЦИЯ** *и. фр.* 1) *махс.* Зур басым астында булган яки зур тизлек белән хәрәкәт иткән сыеклык парларын һәм газларны башка матдә белән кушып, аралаштырып, аларны сирәгәйтеп суыртып алу процессы

2) *гидротех.* Ташу, су басу вакытында турбиналарны гадәти хәлдә эшләтү өчен, су басымын ясалма рәвештә киметү, элекке хәленә кайтару эше

**ЭЗ** *и.* 1) Өслеккә басу нәтиҗәсендә хасил булган, калган сурәт. *Улы белән икәүләп, иртән иртүк торып, яңа яуган кар өстендәге куян эзе буйлап, ындыр артындагы урманлыкка таба чыгып китүләре.* И.Гази. *Җәяүлеләр дә күп үткән булса кирәк --- хатын-кыз ботинкаларыннан калган эзләр ярылып ята.* Ә.Еники

2) Өслектә нәрсәнең дә булса хәрәкәтеннән, күчеп йөрүеннән соң калган сызык, батып кергән урын. *Кар тирән түгел, агач араларында урын-урын чалыш-чолыш сукмаклар, анда-санда ялтырап яткан тасма төсле карлы сызыклар, чана эзләре күренгәли.* Ш.Камал. *Караңгылык куера башлап, тырма эзләре күренмәс булганнан соң, Гөлсем тракторның фараларын яктыртып җибәрде.* Г.Бәширов // Сызык. *Симезлектән ялтырап торган чем кара йон өстеннән аркасында, ялдан алып койрыккача, бераз гына дулкынланып сузылган ак буй эз, шундый ук ак авыз белән ак аяклар бу юрганы мең баш мал арасыннан бер күрүдә әллә кайдан танырлык итеп аерып торалар.* Г.Ибраһимов

3) Тамган, төшеп калган, сибелгән әйберләрнең урынын белдергән тап;

шуларның сузылып барган юлы. *Ике бөртек күз яшем кәгазь өстенә тамып эз калдырды.* М.Гафури. --- *килгән юлында сузылып калган кан эзен күргәч, тәэсирләнә калды.* Г.Гобәй

4) Юл, сукмак. *Отряд, боларны күргәч, болар килгән эздән тауга таба килә башлады.* М.Гали. *Әллә кай тирәнлекләрдән үзенә эз табып килгән су моны күтәрә алмады, кешеләргә рәнҗеп, үз юлыннан кире чигенде, еракка качты.* М.Галләмов

5) Берәр нәрсә белән сугу, бәрү, тырнау һ.б.ш.дан калган тамга, урын. *Менә монда пешкән эз бар, менә монда да бар, менә монда да бар – алар барысы да менә монда сакланалар.* М.Әмир. *Аның кабыргалары беленеп торган ябык аркасында камчы эзләре әле һаман ярылып ята иде.* А.Шамов

6) Йөреш, аяк тавышы. *Бәс, шулай булгач, ястүдән соң, кеше аяк эзе басылгач килерсең.* Т.Гыйззәт

7) *күч.* Эш итүдә, хәрәкәттә, эзләнүдә һ.б.ш.да алган юнәлеш, тоткан юл. *Син салган эз бетмәс, бетермәбез!..* М.Гафури. *Картыннан соң бераз тынычланган кебек булса да, ындыр артында үпкәләп калган Газизе күз алдына килде дә уйларын яңадан элекке эзгә борып җибәрде.* Г.Бәширов. *Нык ышана, беләм, Ул аларның Үзе сызган көрәш эзеннән чыкмасына.* Ә.Исхак

8) *күч.* Берәр психик кичерешнең билгесе, кеше йөзендә, күңелендә, уенда чагылышы. *Аның йөзендә хәсрәт эзләре.* М.Фәйзи. *Аның шулай ямьсез, бәйләнешсез сөйләвенә укытучының йөзендә кәефсезләнү эзләре күренде.* А.Әхмәт

9) *күч.* Берәр вакыйганың яки кемнең дә булса эшчәнлегенең һ.б.ш. нәтиҗәсе, тәэсире. *Бу трагедия үткәнгә хәзер инде байтак еллар кичте, шулай да эзе тирән иде әле.* Г.Ибраһимов. *Җирне җимереп киткән давыл эзен Тынлык сулышлары бизәрләр.* Ә.Ерикәй

10) *күч.* Берәр сүз, күренеш, вакыйга һ.б.ш.ның тәэсире, шулардан соң калган хис. *Юк, бу шакшы сүзләрнең пычрак эзен кайнанасының күз яше юып төшерә алмый иде инде.* Г.Бәширов. *Читтән кайтканнарның үзгәрмичә калган болын-таулар арасында үткәндәге эзләрен хәтерендә яңартып йөрүләрен гомере буе авылдан беркая чыкмаган әни каян инде аңласын.* М.Галиев

11) *күч.* Берәр нәрсәне ачыкларга, ачыкларга ярдәм итә торган билге, җеп очы. *Хәзер туташның кызларыннан берсе алтын йөзек эзе белән монда килә.* М.Фәйзи

◊ **Эз бутау** *к.* **эз яшерү**. *Җинаятьләрен яшерү өчен, мәетне яндырырга булалар. Машина үтеп киткәч, чыбык өеменә ут төртәләр дә --- эз бутамакчы булып, каенлыкка барып чыгалар.* М.Насыйбуллин. *[Җинаятьчеләр] иреккә чыккач, эзләрне бутау өчен, икесе ике якка юнәлгән.* Кәеф ничек? **Эзгә басу** 1) Ау вакытында җәнлекнең эзен табу. *Киекнең эзенә басу*; 2) Җинаятьче, качкын һ.б.ш.ның кайдалыгын белеп алу, эзләп табу. *Ул банда-мазар турында шикләнүдән бигрәк, --- кемнеңдер үзеннән алда өлгереп эзенә басуын уйлап сикереп торды.* М.Гали. *«Милицияне эзгә бастырмам», – ди торган булды ул [Коля], кәеф-сафа корып йөргән чакта.* М.Насыйбуллин; 3) Кемнең дә булса артыннан калмыйча йөрү; берәүгә ияреп эш итү; 4) *к.* **эзгә керү**. *Аның иҗаты революциядән соң да тиз генә тиешле эзгә басып җитә алмый.* Г.Гали. **Эзгә керү** 1) Тормыш, эш уңай якка үзгәрү, юлга салыну, бер җайга керү. *Тик тормыш агышы Гафифә хыялланган эзгә кермәде.* Ә.Моталлапов; 2) Тәртипләнү, төзәлү. *Азып-тузып күп йөргәч, бу бала, ниһаять, эзгә керде.* **Эзгә көл сибү** Берәр кешегә карата начар теләктә булу, башка әйләнеп кайтмавын теләп озату. *Бар, китә бир! Эзеңә көл сибеп калырбыз.* Н.Фәттах. **Эзгә салу** 1) Көйләү, рәтләү, ясау. *Илдархан, карлыганның юан ук ботагына кискечнең көче җитмәгәч, бакча пычкысын алды, әмма аны эзгә сала алмыйча азапланды ---.* М.Хуҗин; 2) Җайга салу, нормаль хәлгә кертү. *– Туганлашып җибәрикме әллә, дип киңәшкә килдек, Шакир кордаш, – диде Нәгыйм абзый, карчыгы сүзне эзгә салып җибәргәч.* Р.Айзатуллин. *Беренче җәйдә үк кызыл туй ясадык үзләренә... Тапты ул эзләгәнен. Тормышын бер эзгә салды.* Э.Касыймов. **Эзгә салыну** Җайлану, көйләнү. *Әлбәттә, бу – минем тормышым бөтенләй эзгә салынмаган килеш, тәртипсез бара дигәнне аңлатмый.* Ф.Фәткуллин. **Эзгә төшерү** *к.* **эзгә салу**. *Кәкүшев җыелышны йомшаграк эзгә төшерә алды. Каты бәрелүчеләрне тиз туктатты.* Х.Камалов. **Эзгә төшү** 1) Кешенең яки җәнлекнең кайдалыгын белү; берәр нәрсә турында мәгълүмат булдыру. *Әгәр аңа мәгълүм булмаган кешеләр кагылган булса, күп вакыт, эзенә төшеп, югалган малны таба иде.* Г.Ибраһимов. *«Илне ике урасам урармын, барыбер эзенә төшми туктамам», – дип үҗәтләнеп тотынды ул.* Ф.Яруллин; 2) *к.* **эзгә керү** (*1 мәгъ.*). *Син, Нәҗия, бер дә борчылма, бар да җайланыр, бар да үзенең эзенә төшәр ---.* Ә.Еники. *Температураң болай эзенә төшеп килгән төсле ---.* Г.Бәширов. *Участокта эш бераз эзгә төшеп бара.* А.Гыйләҗев; 3) Аңлау, төшенү. *Сөйлисе нотыгы буталган, тиз генә эзенә төшәрлек түгел иде.* Н.Гыйматдинова. *Шулкадәр үгет-нәсыйхәт, киңәш биреп тә, Зәмзәмиянең эзгә төшмәвенә гаҗәпләнде.* Ә.Моталлапов. **Эз дә басмау** Берәр җиргә моннан соң бармау, килмәү; суыну, күңел бизү. *Әмма Наилә белә: Гөлнара ул көнне китапханәгә эз дә басмый ---.* А.Гыйләҗев. *Мөбәрәкша үз авылына кайтып төпләнмәкче булган. --- Кайтса, әлбәттә, моны танучы юк: сугыш беткән елны Ижаугa кайтышлый кереп чykканнан бирле авылына эз басмаган икән.* М.Мәһдиев. *Зур укуларда укы, олан! Бүтән авылга эз дә басма!* Н.Гыйматдинова. **Эздән җилләр искән** Югалган. *--- ләкин, кызның эзеннән җилләр искән, ул юк иде, юк ---.* С.Җәлал. **Эздән саптыру** Юлдан яздыру, саташтыру. *Кызу канлык шулай – ул кешене саптыра эздән.* Ф.Агиев. **Эздән чыгу** 1) Тормышның гадәти агышы, эшләрнең гадәти барышы бозылу, чуалу. *Юк кына бер сүз тормышны эздән чыгарды*; 2) Кем дә булса моңа кадәр булган үзенең гадәти тотышын, гадәтләрен (гадәттә начар якка) үзгәртеп, башка төрле яши башлау. *Ә ул көлә генә: «Юкка борчыласың, – ди, – мин бит алай эчәсе килгәннән түгел, ирләр гадәте буенча гына», – ди. Көннән-көн начарлана гына бара. Тәмам эздән чыкты кеше.* Ф.Галиев. **Эздән яздыру** Юлдан яздыру, аздыру, начар юлга этәрү. *Бу сары марҗа безнең институт ирләрен бөтенләй эздән яздырды.* **Эздән язу** Юлдан язу, ялгыш юлга басу. **Эзе дә булмау** 1) Берәр җиргә барып та карамау, анда бөтенләй булмау; 2) Юкка чыгу, китү; *Биючеләрнең эзе дә юк. Кай арада качып киткәннәр.* Һ.Такташ. *Җинаятьченең туфлиен дә, оекбашын да салдырып карадык. Документның үзе түгел, эзе дә юк.* М.Насыйбуллин; 3) *боер. ф. форм. сөйл.* Кемне дә булса кисәтеп, аның килеп-китеп йөрүен тыю. *Бар, себерке, эзең дә булмасын бу йортта!* Г.Тукай. *Бусы черек, бусы нә-*

*зек, дия-дия, күпме агачны екканнар. Икенчеләй эзләре булмасын.* Н.Гыйматдинова. **Эзе дә калмау** 1) Бөтенләй юкка чыгу, башка җиргә китү. *Хәзер инде бер көнге солдатларның эзләре дә калмаган.* Г.Тукай. *Кичәге болытларның эзе дә калмаган.* Г.Ибраһимов; 2) Вакыт узу белән нәрсә дә булса җуелу, югалу. *Әйе бу – кадерле мирас, кыйммәтле мирас! Мәгъмүр Болгар шәһәрләре, Болгар авыллары бер дә булмаган төсле кырылдылар да беттеләр, эзләре дә калмады.* Г.Тукай. **Эзе дә күренмәү** *к.* **эзе дә булмау**. *Аюны аулаган вакытта синең эзең дә күренмәде бит!* Г.Тукай. **Эзе дә юк, исе дә юк** *к.* **эзе дә калмау**. *Әлхасыйль, аучылар бөтен урманны актардылар: бүренең эзе дә юк, исе дә юк.* Р.Төхфәтуллин. **Эзенә басу** Дөресен әйтү, хак әйтү, бик урынлы әйтү. *– Элекке хатының да шикаять күтәреп чыгып йөрмәсен. Дөресме? – Нәкъ эзенә бастың бит, малай, – диде Шамил.* М.Насыйбуллин. *– Салават күпере атала. – Син нәкъ эзенә бастың. Әниеңә дә: «Сиңа салават күпере бүләк итәбез!» – диген.* Р.Кутуй. **Эзенә кайту** Элеккеге, гадәти хәлгә кайту. *Тора-бара барысы да иске эзенә кайтты: эчү, кәеф-сафа кору, тавыш-гауга...* М.Насыйбуллин. **Эзен дә күрмәү** Бөтенләй күрмәү, таба алмау. *Мирза кызларын сөю түгел, баскан эзләрен дә күргәнем юк.* М.Фәйзи. **Эзен корыту** Берәр җиргә килеп йөрүне туктату, тыю. *Гайбәтче Мәдинәнең эзен корыттык, безгә хәзер килеп йөрми.* Мәдәни җомга. **Эзен кыру** Бөтенләй юк итү, юкка чыгару. *Ил озата бүген үз улларын Шаулап торган сугыш кырына. Тыныч илнең изге чикләреннән Дошманнарның эзен кырырга.* Ә.Исхак. **Эзен себертү** Кудырту. *Гитара дөмбердәтүче малай-шалай булса, милициягә әйтеп эзләрен себерттерер идең, бу тел бирәннәренә ни милицияң, ни законың.* Ф.Яруллин. **Эзеңне себер** *боер. ф. форм. сөйл.* Кемне дә булса кисәтеп, китәргә, башка килмәскә кушканда әйтелә. *– Юк бул! Эзеңне себер, җирбит! – дип очынып килгән Мәдинә тегенең җилкәсенә берәр тапкыр менеп төшәргә өлгерде, ахрысы.* М.Хәсәнов. **Эз җую** *к.* **эз яшерү**. *Үз эшләреннән үзләре калтырап калган җинаятьчеләр, бер-берсен сүзсез аңлаган төсле, эзләрен җую өчен, артларына да карамыйча арбага ашыктылар.* Г.Минский. *Ләкин хикмәт анда түгел: Без иң олы, иң куркыныч кимчелекнең Җуйдык эзен.* З.Мансур. **Эз калдыру** 1) Билгеле рәвештә тәэсир итү, хис калдыру. *Ә бу җырның тарихы минем тормыш юлында якты эз калдырган ниндидер романтик һәм саф хис иде.* Ә.Рәшитов; 2) Үзеннән соң башкалар күрерлек, искә алырлык эш-гамәл калдыру. *[Картлар] гомер буе колхозда эшләгәннәр, үткән тормыш юлларында якты эз калдырганнар.* М.Насыйбуллин. **Эзне дә күрсәтмәү** *к.* **эзе дә булмау**. **Эз салмау** *к.* **эз басмау**. *Китәм мин колхоздан, көлмәсен миннән райком секретаре. Эз салмыйм Бәешкә бүтән.* Г.Тавлин. **Эз салу** 1) Кайда да булса булу, йөрү; еш бару; 2) Берәр җиргә беренче булып керү, аяк басу; нинди дә булса эштә башлап йөрү. *Шулай да тынычсыз малайлар үзләренең иҗат эзләрен салып өлгергәннәр иде.* Г.Ибраһимов; 3) Тормыш юлын башлау, киләчәк максатны билгеләү. *Мин тайгада ачкан юллар белән Килсен ул, әйт, минем яныма. Без бергәләп якты эз салырбыз Шат яшьлекнең гөлләр тавына.* Ш.Маннур. **Эз саташтыру** *к.* **эз яшерү**. *Алар, эз саташтыру өчен, якын тирәдә ары-бире килеп, яңа эзләр ясаштыргалап йөргәннән соң --- куе агачлыклар арасына --- күчтеләр.* М.Гали. **Эз себерү** *мыск.* Яңадан килмәс булу, качып котылу; нәрсәне дә булса юкка чыгару. *Мәтәлделәр үләт козгыннары. Калганнары – эзен себерде.* Ш.Маннур. *Бик шома, хәйләкәр булып чыкты бу Степанов, кем әйтмешли, бөтен эзләрен себергән.* Ф.Галиев. *Мин өчкә кадәр санаганчы, моннан эзеңне себерәсеңме, әллә...* Г.Шакирова. **Эз суыну** 1) Кем яки нәрсә дә булса юкка чыгу, башка күренмәү. *Сезнең спектакльне тәнкыйтьләгәннәр икән!.. Шуннан бирле бездән эзегез суынды.* А.Гыйләҗев. *Артистның иң бөек максаты – үзен уйнау! Бәлки, шуннан соң театрдан эзем суыныр, чөнки, максатыма ирешкәч, мин гап-гади кешегә әйләнермен.* Н.Гыйматдинова; 2) Кая да булса барып йөрүдән туктау, бармый башлау. *Шушы хәлдән соң бәхетле хатынның эзе тәмам суынды, безнең өйдә күренмәс булды.* Р.-Н.Гүнтәкин; 3) Истә булмау, хәтердән чыгу, онытылып бетү. *Ташаяктагы аксак солдатның саф халык телендә, әле йөрәкләрдә әрнеткеч эзе суынмаган сугыш турында җырлавы бикбик тансык иде.* Ә.Фәйзи. **Эз суыту** Берәр җиргә барудан тыелу, туктау. *Көн дә алачык төбенә килеп баса торган «Москвич» та, зәңгәр күзле егет тә яңгырлар башланганнан бирле эзләрен суыттылар.* К.Тимбикова. *Аңлашмыйм, кит, дим сиңа, кит. Бүтән күземә күренмә, югал, эзеңне суыт.* Н.Гыйматдинова. *Хәер, уртанчы кыз туган йортка эзен суытмады – гел кайтып йөрде.* Р.Мулланурова. **Эз югалту** *к.* **эз яшерү**. *Без алардан ничек кенә булса да сугышсыз качып котылырга, эзебезне югалтырга тырышып карадык, ләкин булмады.* А.Шамов. *Санька-анархист. Дардиев Газыйм... Һәммәсе дә безнең күзгә чалынган бәндәләр. Шуңа күрә аларны берәм-берәм юк итә баралар да. Эз югалталар.* З.Фәтхетдинов. **Эз югалу** Юкка чыгу. *Тик бер көнне солдат Яһудинны «махсус бүлек» чакыртып алды. Алды, һәм --- шул көннән соң аның эзе югалды.* М.Мәһдиев. **Эз яздыру** *к.* **эз яшерү**. *Менә болар бар да полициянең нык керешкәнен, инде эз яздыру мөшкел булачагын күрсәтәләр иде.* Г.Ибраһимов. *Артыңнан дүрт күз белән йөгергән малайларны эз яздырыр өчен чалыклыйчалыклый, үләнле төштәрәк [чөйне] төшереп калдырасың.* М.Галиев. *Серадов исә, берни булмагандай, кул биреп күреште: – Әзрәк эз яздырыгыз да «Пассаж»га килегез.* З.Фәтхетдинов. **Эз яңарту** Кабат күренмәү, күзгә чалынмау. *Салихҗанга ике яшь тулгач, күтәренеп, каядыр чыгып китте дә шуннан бүтән авылда эз яңартмады.* Н.Гыйматдинова. **Эз яшерү** 1) Юнәлешне үзгәртеп, эзне беркем таба алмаслык итеп бутау, эзне саташтыру; 2) Берәр эштә гаепне таба алмаслык итеп, гаепне күрсәтә торган билгеләрне, фактларны юк итү. *--- йөргән эзен яшерү өчен ничаклы чараларга керешсә дә, «без капчыкта ятып кала алмас, ди».* Г.Ибраһимов. *Өч көн буена төлке кебек эз яшерергә маташып йөргәнсез икән, оятсызлар.* М.Насыйбуллин

**ЭЗӘР** *и. фар.* Бизәкле тукымадан яки шнурдан үреп эшләнгән билбау. *Ул ---, ни хикмәттер, ак яулыкка төренгән, шуның өстенә, чәчәкле-чуклы тагын бер яулыкны эзәр итеп, киң маңгаен каплап будырган.* К.Кәримов. *Гата --- Заһит абыйның билендәге эзәрен чишеп алды һәм шул эзәре белән кулын каерып бәйләде.* В.Нуруллин

**ЭЗӘРЛӘҮ** *ф.* 1) *к.* **эзәрлекләү**. *Дошманнарны мин эзәрлим – Минем кулда автомат.* Ә.Ерикәй. *Югыйсә үземне эзли яки эзәрли калсалар, тәтәмә*

*каршы бернинди дә киртә куя алмас идем.* Р.-Н.Гүнтәкин

2) Яшерен күзәтү, шымчылык итү. *Моңарчы аны эзәрләүләр сизелми иде. Бу беренче тәҗрибә булды. Шик юк, диләр. Ләкин кемне күзәтә? Таңгатарның үзенме? Әллә, Госман җыелышында кемнәр булды, дип, барын дә эзәрлиләрме?* Г.Ибраһимов. *Хәтта күршебездәге кулакның (хәзерге җизни атасының) кайда икмәк яшерүен эзәрләп, Кимга хәбәр иттем.* С.Баттал

3) Тикшереп нәтиҗә ясау, ачыклау; тәфтиш итү. *Фәхринең үтерелүендә гаеплеләрне эзәрләү төене әнә шулай башланып китә.* Г.Нигъмәти

4) *күч.* Уйлап, логик фикерләп төшенү, аңлау. *Сүзләр арасындагы мәгънәне эзәрләү. Кинаядәге мәгънәне эзәрләү*

**Эзәрләп алу** Кыска гына вакыт эзәрләү

**Эзәрләп йөрү** Озак вакыт дәвамында, шактый озак эзәрләү. *Әле күптән түгел генә бер терелеп килүче лейтенант аны [Асяны] шактый эзәрләп йөрде.* Х.Камалов

**Эзәрләп тору** Һаман, гел, бертуктаусыз эзәрләү. *Саммер менә шул яшерен склад эше белән китте, аны бер минут күздән яздырмый, эзәрләп торыгыз... ди.* Г.Ибраһимов. *--- бу җәнлекләрнең тиреләре бик әйбәт, җылы һәм матур булганга, аларны аучылар һаман эзәрләп торганнар.* Дөньяда ниләр бар?

**Эзәрләп чыгу** Бар булган җирдән эзәрләү. *Гаскәрләр һәм аучы-сунарчылар, йөгерек аргамакларга менеп, Камәрҗаннар киткән дала, яланнар, елга һәм күлләрне аркылысын-буен эзәрләп чыктылар.* К.Насыйри

**Эзәрли башлау** Эзәрләргә тотыну, эзәрләргә керешү. *Боҗырлар башка урынга очып киттеләр. Яша аларны эзәрли башлады.* Дөньяда ниләр бар?

**ЭЗӘРЛӘҮЧЕ** *и.* Эзәрлекләүче. *Бераздан ату тавышы тагын кабатланды, аннары бик тиз якынлашып килгән аяк дөпелдәве ишетелде – дуамал чабуына караганда, бу дошман эзәрләүче кеше йөрешенә бер дә охшамаган иде.* Т.Әйди. *Учак янындагы әлеге хәл мине эзәрләүчеләрнең дә игътибарын җәлеп иткән, ахрысы: алар, капланган чиләк янында туктап, кискен ишарәләр белән балыкчыга нидер аңлатып торалар иде.* Р.-Н.Гүнтәкин

**ЭЗӘРЛЕ** *с.* Эзәре булган, эзәр булган. – *Әй, ат түгел ул сиңа Миңнулла абый, – диде кызыл эзәрле, кара сакаллы кеше...* И.Гази

**ЭЗӘРЛЕКЛӘ́Ү** *ф.* 1) Тотарга, юк итәргә теләп, кемнең дә булса артыннан куып бару. *Опанасның өс-башы пычракка баткан, үзе, аучылар тарафыннан эзәрлекләнгән аю сыман, авыр сулый ---.* Г.Әпсәләмов. *Ул китмәкче булган иде, милиционер туктатты: «Гражданин, сезнең документыгыз? Нәрсәгә бу иптәшне эзәрлеклисез?».* Ф.Яруллин

2) Ирекле эшләргә, яшәргә мөмкинлек бирмәү; кысрыклау, җәберләү. *Гаебем булса, хөкемгә тартыгыз, соңгы сүзне суд әйтер. Юк икән, эзәрлекләүне туктатыгыз.* М.Насыйбуллин

3) *күч.* Баштан, уйдан китмәү, күңелдә калу. *Кешеләр кумаса – оятым куды. Шул нәрсә мине гомерем буе эзәрлекләде.* Ф.Яруллин. *Мәдинәнең соңгы тапкыр очрашкандагы ул күз карашы Борһанны байтак вакыт эзәрлекләде.* М.Хәсәнов

**Эзәрлекләп алу** Билгеле бер вакыт дәвамында эзәрлекләү. *Шушы көннән башлап әлеге коткылы уй --- картны эзәрлекләп алды да китте.* Казан утлары

**Эзәрлекләп йөрү** Озак вакытлар дәвамында эзәрлекләү. *Владимир каласына күченгәннән бирле, Андрейны Вышегород рухание кисәткән сүзләр эзәрлекләп йөрде.* В.Имамов. *Ләкин төлке аны гел эзәрлекләп йөргән.* З.Мурсиев

**Эзәрлекләп килү** Күптәннән, электән бирле эзәрлекләү. *Ветераннар сугыш эзләреннән йөри, ә ул аларның үзләрен эзәрлекләп килә.* М.Вәлиев. *Теге чактагы яңгырлы төн аны көннәр, айлар эченнән һаман да эзәрлекләп килә.* Р.Низами

**Эзәрлекләп тору** Һәрвакыт, даими эзәрлекләү. *Ниһаять, хазарларның эзәрлекләп торуына түзә алмыйча, болгарларның өченче төркеме --- Идел һәм Чулман (Кама) буйларындагы урман-далалар куенына килеп сыена.* М.Мәхмүтов. *Бары тик Мартукка бакыр комбинаты һәм башка комбинатларның гомер бетмәслек булып сеңгән күкерт һәм аммиак исләре генә аны һаман эзәрлекләп тора шикелле.* Р.Мирхәйдәров

**Эзәрлекли башлау** Эзәрлекләргә тотыну. *Эзәрлекли башласалар, тотам да сестра Маринаның хөҗрәсендә качып калам, димен.* А.Гыйләҗев. *Пугачёв явы кузгалу белән, хөкүмәт нәшрият эшен эзәрлекли башлый.* М.Вәлиев

**ЭЗӘРЛЕКЛӘҮЧЕ** *и.* 1) Кемне яки нәрсәне дә булса куып баручы. *Хәер, танышып китте дигәч тә, ул чакта, егетнең машинасына кереп утырган шушы беренче көнне, дөресрәге, төнне, Фатыйма үзен эзәрлекләүче бу егетнең исемен генә белеп калды бугай ---.* Ә.Сафиуллин

2) *сөйл. к.* **эзтабар**

**ЭЗБАСАР** *и.* 1) Хайваннарның эзләрен таба, аера, шулар белән аларны эзләп таба белә торган аучы. *Эзбасарлар өчен иң кулай вакыт – кыш инде ул*

2) *к.* **эзкуар**. *Ул арада кинолог белән эт тагын ешкынлык эченә кереп югалдылар. Эзбасарлар текә ярдан чокыр төбенә тәгәрәп диярлек төштеләр.* Ф.Галиев

3) Эзәрлекләүче, эзләүче. *Әмма яралы эзбасардан хаҗиның һәм яраннарының алдан әзерләнгән яшерен урыннарын әйттерә алганнар.* Ф.Сафин

4) Дәвамчы. *Бөек Октябрьгә егерме ел тулганда, ничек инде шул революцияне үз куллары белән барлыкка китергән, аны саклап калу өчен кан түккән ветераннар, аларның эзбасарлары – яшьләр, комсомоллар – төрмәдә утырсын? Акылга сыймый.* И.Салахов

**ЭЗГӘ́-ЭЗ** *рәв.* 1) Бер-бер артлы, берсе баскан эзгә икенчесе басып. *Уртадан эзгә-эз атлап баручыларның берсе – бөкрәйгән гәүдәле, олтанлы итекле минем әти...* М.Мәһдиев. *Бик сирәк вакытта, әлеге хакыйкатьне кабул итмәүчеләргә генә кырыс, үткен чагыштыруларын китерә иде ул: эзгә-эз атлаучы бүре өере һәм иң алда, әлбәттә, өер башы.* М.Сәлимҗанов

2) Калышмыйча, артыннан ук. *Гузанов күп сәләтләргә ия: язучы да, артист та, режиссёр да, рәссам да, --- заман белән эзгә-эз басып атлаучы патриот та.* Г.Тавлин

3) Бик төгәл, тайпылышсыз. *Иван Бунин, мәхәббәт өлкән яшьтәге кешеләрдә, җиргә якын затларда --- гына була, дигәнрәк фикер әйткән. Мин аның сүзләрен яттан, эзгә-эз әйтә алмыйм.* Т.Галиуллин

**ЭЗЕННӘН** *бәйл.* 1) Берәр максат белән, шуның өчен, шуның артыннан, шул юлда. *Дошман йөри аның эзеннән.* Н.Исәнбәт. *Менә байтак заманнар инде Җәләл мулла [Зыяның язмышын үзгәртерлек бер таяныч табу] эзеннән йөри.* Г.Ибраһимов

2) Кемнең яки нәрсәнең дә булса тәгълиматына ияреп, үрнәк алып, артыннан

**ЭЗКУАР** *и.* Эз буенча барып, киекне, кешене яки башка нинди дә бул-

са нәрсәләрне табарга өйрәтелгән эт. *[Көчек] Баскычны исни, Ишекне исни: Борыны белән Укый адресны! Әткәй мактады: – Моннан эш туар – Имтихан үтте Синең эзкуар!* Ш.Галиев. *Эзкуар ярдәмендә җинаятьчене табу*

**ЭЗЛӘГЕЧ** *и. махс.* Электр үткәрмәүчән мохит (җир, су, агач һ.б.ш.) эчендә яткан теләсә нинди металл әйберләрне табу өчен сизгер прибор. *Стена буенда урын бушауга, криминалист, тагын металл эзләгечен алып, металл күмелгән урынны төгәл билгеләде.* Ф.Галиев. *Шунда үзен, урта мәктәп тәмамлап, мина эзләгечнең тимертомыр яткан җирне генә күрсәтә алуын, алтын-көмешнең аңа бөтенләй тәэсир итмәвен дә белмисеңмени, дип әрләп ташладым.* Ә.Сафиуллин

**ЭЗЛӘНҮ** I *ф.* 1) *кайт. юн. к.* **эзләү**. *Карлыгач, тезләнеп йөри-йөри, камыш төпләреннән нәрсәдер эзләнә ---.* Г.Гобәй. *Зиннәт мәш килеп эшләп йөргән шушы чуар халык арасыннан күзләре белән эзләнә ---.* Г.Бәширов

2) Камиллеккә омтылу, ачыш ясарга тырышу. *Кыш буена Фәйрүзәнең --- Орлыкларга сынау ясап, Нәрсәдер эзләнүе Юкка булып чыкмады.* М.Җәлил

3) *күч.* Тынычсызлану, борчылу, нидер теләү, үзеңә урын таба алмау. *Ә шулай да күңел эзләнде. Сорамыйча, иркәм, түзмәдем.* Ф.Кәрим. *Күңелем нәрсәнедер хәтерләтергә тырышып эзләнә, мин, ни әйтергә белмичә --- җавап көтә идем.* М.Әмир

**Эзләнә башлау** Эзләнергә тотыну. *Муса миңа әйтә: «Бөтен кеше күкрәкләренә кызыл тасма таккан, безгә дә тагарга кирәк», – ди. Без борылып кердек тә эзләнә башладык.* Р.Мостафин. *Эскәмияләрдән дәррәү торып, тартырга эзләнә башладылар.* Х.Камалов

**Эзләнә тору** Башка эш-хәрәкәт барышында эзләнү белән шөгыльләнү; шактый озак эзләнү. *Рәхим, --- эзләнә торгач, тагын биш-алты кушанкы тапты.* А.Вергазов. *Эзләнә торгач, ул Каюм остазның яхшы тун, модный тар чалбар киеп йөргәнлеген ачыклый.* Р.Батулла

**Эзләнә төшү** Тагын да ныграк, күбрәк эзләнү. *Тикшерә, эзләнә төшсәң, баш миендә эндорфиннарны ясалма рәвештә барлыкка китерә торган препарат эшләп чыгарырга --- мөмкин булыр иде.* Ә.Баян. *Начар язмый ул, күп эзләнә торган шәхес. Язсын тагын, эзләнә төшсен, начарга язмый бит.* Д.Исхаков

**Эзләнеп алу** Тиз генә, кыска вакыт эзләнү. *Гайсә ---, Әнзирәне капшап, нидер эзләнеп ала.* Г.Каюмов

**Эзләнеп тору** Эзләү процессында булу; гел, һәрвакыт эзләнү. *Нәрсәдән көләргә дип эзләнеп торган килендәргә, кызларга бу җитә калды ---.* Г.Ибраһимов. *Шул кадәресен ачыклагач, башка эзләнеп торырга минем вакытым да һәм, турысын әйтергә кирәк, теләгем дә булмады.* И.Хуҗин

**ЭЗЛӘНҮ** II *и.* 1) Эзләнү (I) процессы. *Җидееллык мәктәп аның бу соклануын, бу эзләнү дәртен көчәйтте генә. Күңеле – яшьләрне көнләштерердәй. Тик тормый, гел эзләнә, бәхәсләшә, нәрсәнедер инкарь итә, раслый.* Ә.Рәшитов. *Дарвинны дәвам иттерүче Иван Владимирович Мичуринның күпьеллык эзләнү һәм хезмәт казанышлары үзенең әһәмияте ягыннан бик зур.* А.Бахарев, П.Яковлев

2) Тикшеренү, берәр өлкәдә ачыш, яңа юллар, чишелешләр табуга юнәлгән эш, шундый процесс. *Бу терминнар очраклы табыш түгел, шактый уйланулар, эзләнүләр нәтиҗәсе иде.* А.Тимергалин. *Сәнгать корбаннар сорый дип, --- ул һаман театрда эзләнә ---. Эзләнүләрдә ярдәм кирәк, ә мин ерак ---.* М.Маликова

**ЭЗЛӘНҮЧӘН** *с.* Эзләнергә ратучан, тынгысыз, кызыксынучан. *Тынгысыз, эзләнүчән кеше торган саен үз иҗатында яшь тармаклар җибәрә.* Ф.Яруллин. *Галимнәр, ягъни уйлый, фикерли белә торган кешеләр, эзләнүчән җаннар – бөек хакыйкатькә барып җиткән кешеләр.* Ф.Бәйрәмова

**ЭЗЛӘНҮЧЕ** *и.* Фәнни тикшеренүләр белән шөгыльләнүче белгеч. *Урмандалаларда, тауларда эзләнүче, тикшеренүче галимнәр, сәяхәтчеләр, көтүчеләр, балыкчылар белән әңгәмәләр кордык.* Р.Фәизов. *Күп вакыт тарих шулай языла ич. Беренче эзләнүче: «Шулай түгел микән?» – дип фараз кыла. Икенчесе: «Шулай!» – дип тәвәккәлли.* М.Галиев

**ЭЗЛӘ́Ү** *ф.* 1) Билгеле әйберне табарга тырышып, төрле урыннарны карап чыгу. *Хәлим үлекләр арасыннан теге чуар сарафанлы хатынны эзләде, ләкин ул алар арасында юк иде.* А.Шамов. *Авыл халкы, җир кардан әрчелгәч, көрәк белән казып, бакчадан черегән бәрәңге эзли.* С.Поварисов

2) Яңа чыганаклар табу белән шөгыльләнү. *[Иванов] Сез, Рәхимә туташ, нефть эзләп, егет табып куймагыз тагы.* А.Әхмәт. *Безнең кызлар, алтын эзләп, Разведкада йөриләр.* Ә.Ерикәй

3) Лаеклы, кирәкле, яраклы һ.б.ш. кешене яки әйберне табарга тырышу; сайлау. *Шул исемсез бөек шатлыгы уртасында уянган хисләренә ашыга-ашыга исем эзләвен, таба алмый газаплануын карап тордым.* Һ.Такташ. *Ул, кызын юатыр өчен, матуррак, ягымлырак сүзләр эзли.* А.Шамов

4) Нәрсәгә дә булса омтылу, ирешергә максат кую. *Алар бу вакыт эчендә ничек кенә булса да акланып калырга юл эзләделәр.* Г.Гобәй. *Гафият үзенең бәхетен гомер буе җирдән эзләде.* И.Гази. *Аның «җылы урын» эзләгәнен белмисеңмени?* Г.Әпсәләмов

5) Берәр яңалыкка яки яхшырак нәрсәгә омтылу. *--- бу мастер һәр постановкасында яңалык эзли ---.* М.Җәлил. *Карашы тәрәзәдән ачылган шәһәр өстенә төбәлгән, уйчан күзләре безне күреп-өйрәнеп бетергән, инде бүтән яңалык эзли кебек иде.* М.Хуҗин

**Эзләп бетерү** Бөтен җирдән дә эзләү. *«Бәлки, сез эшләп-эзләп бетермисездер?» – дигән сорау белән «Татар моңы» конкурсының башкаручы директоры Вил Усмановка мөрәҗәгать иткәч: «Моны безнең эзләп бетермәү дип аңларга кирәкми», – дип җавап бирде ул.* Шәһри Казан. *Каян гына эзләп бетермәделәр, Актәпи бер җирдә дә юк.* Шәһри Чаллы

**Эзләп чыгу** Баштан ахыргача эзләү. *Хуҗасының югалган төненнән хәзергәчә бер минут туктамыйча, бөтен урманнарны, тауларны актарып эзләп чыккан Акбай үзе артыннан ияргән кешеләрне менә шул биек ярлы Яманкулга китерде.* Г.Ибраһимов. *Эзләп чыкты чоланнан да – Бушка гына ләкин бар да! Юкка чыкты күзлек шулай ---.* Ш.Маннур

**Эзли башлау** Эзләргә керешү. *--- минем уйны гел Таңсылу биләп ала; аны күрер өчен генә дә кырык җирдән кырык сылтау эзли башлый идем.* Х.Сарьян. *Мира кузгалды да, сүзем бетте, дигән шикелле, шкафы янына килде, аны ачып, нидер эзли башлады.* Х.Камалов

**Эзли тору** Башка эш-хәрәкәт барышында эзләү белән шөгыльләнү; озак вакытлар буена кабат-кабат эзләү. *Эзли торгач, Утар ягындагы сазланган ташландык җиргә кудырырга булдылар.* Р.Мостафин. *Күп эзли торгач ул, ниһаять, Козлов шәһәре тирәсендә --- ташландык җир таба.* А.Бахарев, П.Яковлев

**ЭЗЛӘҮЧЕ** *и.* Нәрсәне дә булса эзләү, табу белән шөгыльләнүче. *Без, бәхет эзләүчеләр, икебез ике эз белән китеп, бер-беребездән адашачак.* М.Фәйзи.

*--- Шилка һәм Амур суы буенда --- юл салмак бик читен булып, бик кыйммәт төшәчәк булгач, җир казучы, юл эзләүче инженерлар тимер юлны Маньчжуриядән үткәреп, Владивостокка чыгаруны мәслихәт --- кылды.* Фән һәм тел

**ЭЗЛЕК** *и.* Эз ясалу, эз төшү өчен мөмкинлек, җирлек, урын. *Җиргә аз гына эзлек төштеме, мин тагын кырда.* Г.Бәширов

**ЭЗЛЕКЛЕ** *с.* **1.** 1) Берсе артыннан икенчесе ялганып бара торган; бер-бер артлы. *Бу иллэрдәге сәнгать Урта гасырларга хәтле алынган темплар белән эзлекле үсешен дәвам иткән.* К.Гыйззәтов. *Г.Рәхимнең мәгънәви кайтавазларга омтылуы шактый эзлекле күренеш икән ләбаса!* М.Вәлиев. *Көнкүрешне аз-азлап эзлекле яңарту, яңа мәдәниятне үстерү исеменә алар башлап үзләре хәлиткеч адым ясыйлар ---.* М.Гайнетдинов

2) Берсеннән-берсе чыга торган (вакыйгалар барышы, нәтиҗәләр һ.б.ш. тур.). *Төзүче-автор Рәшит Галләмов бу китапта татарча тарих терминологиясенең бүгенге торышын чагылдырып кына калмый, бәлки тарих терминнарын эзлекле бер системага сала.* А.Тимергалин

3) Логик нигезләнгән, нәрсәдән дә булса закончалыклы рәвештә килеп чыга торган, алдагыга каршы килми торган, мантыйклы. *Аяклары атласа да, мие, нәкъ паралич суккан кебек, эзлекле фикер йөртә алудан мәхрүм иде.* М.Хәсәнов. *Моның өчен ул документаль нигездә, фактларга гына таянып, мантыйкый эзлекле, шул ук вакытта образлы үтемлелек белән сугарылган фикер йөртә.* И.Низамов

4) Берәр карашка тайпылышсыз иярә торган, үзе тормышта сайлаган юнәлештән тайпылмаган. *Г.Нигъмәти --- шуңа күрә дә бик тиз бер ара эчендә үзен төпле, эзлекле марксист тәнкыйтьче итеп танытты.* М.Мәһдиев. *Иван Владимирович Мичурин эзлекле дарвинист иде.* А.Бахарев, П.Яковлев

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Билгеле тәртип белән, әкренләп. *[Галимҗан кәефен] кичерешләрен һәм хәрәкәтләрен эзлекле итеп үстерергә кирәк.* М.Җәлил

2) Закончалыклы, мантыйклы. *Күренә ки, фикер буыннары монда шактый эзлекле төзелгән: яшь герой, һәр җөмлә саен, мәсьәләнең үзәгенә, яшәү нигезе – хезмәт, дигән нәтиҗәгә таба якынлаша бара.* Ф.Хатыйпов. *Менә мондый шигырьләр белән баланы уйланырга, эзлекле итеп фикер йөртергә өйрәтеп була, чөнки шигырьнең һәр юлы балага сорау бирә һәм баладан җавап эзләтә.* Р.Харисов

3) Даими рәвештә, өзлексез. *Коллективта тәртип ныгыды. --- План эзлекле үтәлә башлады.* А.Гыйләҗев. *Бөтен язганнарын җентекләп белэм дип әйтә алмыйм, әмма шигъри әсәрләрен эзлекле күзәтеп барам.* С.Хәкимова

**ЭЗЛЕКЛЕЛЕК** *и.* 1) Нәрсәнең дә булса барышында, үсешендә, урнашуында билгеле чират, төгәл тәртип, мантыйк; эзлекле булу хәле. *[«Кара йөзләр» либреттосында] вакыйгалар логик эзлеклелек белән үстерелә.* М.Җәлил. *Күңелем ашыгып-ашыгып барысын уята, кузгата башлады, булып узган вакыйгаларны бер җепкә тезеп, эчке эзлеклелек, закончалык табарга кирәк иде.* А.Гыйләҗев. *Бу реакцияләрнең эзлеклелеген схема рәвешендә түбәндәгечә күрсәтергә мөмкин.* Химия

2) *мат.* Нинди дә булса бер закон буенча төзелгән саннар күплеге. *Әгәр эзлеклелекнең теләсә кайсы буынын табу юлы билгеле булса, эзлеклелек бирелгән дип санала.* Югары математика нигезләре. *Дәрәҗә күрсәткече иррациональ сан булганда, $a^s$ дәрәҗәсен табу өчен, иррациональ s санын рациональ саннар эзлеклелегенең чикләмәсе итеп карыйбыз.* Комплекс үзгәрешле функцияләре теориясе нигезләре

**ЭЗЛЕКСЕЗ** *с.* **1.** Эзлекле булмаган; чиратсыз, тәртипсез. *--- хатлар, көндәлекләр ничек кенә буталчык, эзлексез, имгәтелгән җөмләләр белән язылмасыннар, аларда кешенең кайнар йөрәк тибеше ярылып ята ---.* Ф.Садриев. *Вакыты белән аның, хәтта: «Нәрсә эшләсәм дә – ул кирәкмәс, ни әйтсәм дә – ул урынсыз булып чыга... Уйларыма кадәр җирлексез, эзлексез минем. Ничек яшәмәк кирәк?..» – дип, төшенкелеккә бирелгән чаклары да була.* М.Хәсәнов

**2.** *рәв. мәгъ.* Эзлеклелеген югалтып, тәртибе бозылып. *Без бер вакыйгадан икенчесенә тиз күчтек, шулай да эзлексез барган әңгәмәдән мин малай чакта белеп бетермәгән күп нәрсәләрне хәтеремдә калдырдым.* М.Хуҗин. *«Кулакны сыйныф буларак юк итү» шигаре үтә гаделсез һәм эзлексез рәвештә тормышка ашырылды.* Р.Әмирхан

**ЭЗЛЕКСЕЗЛЕК** *и.* Эзлеклелек җитмәү яки бөтенләй булмау күренеше; мантыйксызлык; эзлекле тәртибе булмау. *Аның «Өлфәт» газетасы да башта бик зур абруй казана, ләкин бераздан, үзенең эзлексезлеге аркасында, укучыларын югалта.* М.Мәһдиев. *Гамәлдәге орфография кагыйдәләре буенча, «шигърият» сүзенә нечкә кушымча ялгана. «Әкият», «хикәят», «мәдәният» сүзләренә дә шулай. Мин бу очракта орфографиябездә эзлексезлек күрәм.* А.Тимергалин

**ЭЗМӘ-ЭЗ** *рәв. к.* **эзгә-эз**. *Мин сүзләрен яттан эзмә-эз әйтә алмыйм.* Т.Галиуллин. *«Исемсезләр» романында эзмә-эз, бер калыпка салынган сюжет җебе хәрәкәтеннән бигрәк фикер энергиясе үзенә җәлеп итә.* Р.Харис

**ЭЗНӘК** *и. к.* **эз** (*5 мәгъ.*). *Язын Гатият Миңлебаевның кечкенә малае ул каенның түбәнрәк урынына балта чабып эзнәк ясый ---.* М.Мәһдиев

**ЭЗО́П** *и.* Борынгы Грециядә мәсәл жанрына нигез салучы, фараз белән б.э.к. 6 гасырда яшәгән ярымтарихи, ярыммифик шәхес

◊ **Эзоп теле** Фикерләрне читләтеп әйтүгә нигезләнгән сәнгатьле сөйләм; гомумән, киная, туры сүздән качу. *Әгәр мин шигырьне эзоп теле белән язып, халыкның йөрәгендә кайнаган уй-тойгыларны укучыма җиткерә алсам?..* Ф.Яруллин. *Гаепләүләрне бетенә бәреп әйтә башлагач, ул [Әхмәров], туры җаваптан читләшеп, киная, эзоп теленә күчте.* Т.Галиуллин

**ЭЗОТЕ́РИК** I *с.* Эзотерикага караган, шуңа мөнәсәбәтле. *Бу төшенчәне эзотерик әдәбиятта КосмоЗло (Космическое Зло) дип атап йөрү гадәткә кергән.* С.Шәмси. *Әсәрләрнең сюжеты мифологик персонажлар, вакыйгалар, легендалар, эзотерик күренешләр белән уңышлы үрелеп бара.* Фән һәм тел

**ЭЗОТЕ́РИК** II *и. рус* Эзотерика белгече. *Остаз нәкъ менә шундый: галәмнән килгән нурланыш-хәбәрләрне кабул итә белүче, аңлаучы – эзотерик икән.* М.Маликова. *Ул – профессиясе буенча физик, үзен танылган галим, эколог, эзотерик, укытучы, дәвалаучы дип таныштырырга ярата.* Шәһри Чаллы

**ЭЗОТЕ́РИКА** *и. гр.* Мистик тәгълиматлардан хәбәрдар булмаган кешеләргә аңлашылмый торган белемнәр. *Эзотерика ул – яшерен гыйлемне өйрәнә торган фән.* Р.Сафин. *Нәтиҗәдә чын мәгънәсендәге фән буларак беркайчан да танышмаган астрология, эзотерика, сихер һәм сихерчелек, магия --- халыкның көндәлек тормышының*

*аерылгысыз бер өлеше булып әверелде.* Ф.Урманче

**ЭЗСЕЗ** *с.* **1.** Эз салынмаган, беркем йөрмәгән; өстендә бернинди эзләр булмаган. *Әллә инде юлчы картның өметле сүзләре, әллә урман ышыгы, урман һавасы аның сулышын иркенәйтте, әллә... шушы эзсез сукмакның тылсымлы көче булыштымы?* Г.Гыйльманов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Булган, узган җирендә үзеннән соң бернинди эз калдырмыйча. *Иртән торуга Нибәтулланың төнге күз яше кызу мунча ташына салган су кебек эзсез кипкән була.* Ш.Янбаев. *Кая, ди, ул каеннар – төпсәләре дә эзсез югалган.* А.Хәлим

2) Үзе турында бернинди эз, хатирә, нәтиҗә калдырмыйча. *Ни мәгънә бар эзсез яшәүдә?!* М.Җәлил. *Фазлыев: «Торымнан-торымга каралырга кирәк сиңа, Нәҗип туган, психик чарпалышлар эзсез үтми алар», – дигән иде түгелме?* А.Гыйләҗев. *Әйе, кешенең үткән гомере җирдә эзсез калмасын: чәчәк булып ачылган яшь кеше гомере киләчәккә кызыл алма булып барсын, җимеше-хезмәте киләчәккә ядкарь булсын.* Б.Рәхимова

3) Билгесез, ачыкланмыйча. *Прокуратура, гадәттә, бер генә гаризаүтенечне дә эзсез калдырмый.* М.Насыйбуллин. *Урланган маллар, суга баткандай, эзсез югала.* Н.Әхмәдиев

**ЭЗСЕЗЛЕК** *и. к.* **эзлексезлек**. *Ичмасам, Аллаяр да безгә килми башлады, үземнең эзсезлегем белән аны да үпкәләттем.* Ф.Мансуров. *Борын-борыннан ук билгеле: тәрбия бала тугач та башлана, һәм баланың киләчәктә үзе-үзе тотышындагы, яшәвендәге чатаклыклар (көйсезлекләр, тискәрелек, тотнаксызлык, эзсезлекләр, елаклык --- һ.б.) – начар тәрбия нәтиҗәсе.* Яшел Үзән

**ЭЗСЕ́З-ХӘБӘРСЕЗ** *рәв.* Үзеннән соң бернинди дә эз калдырмыйча, үзе турында бернинди хәбәр бирмичә. *– Эзсез-хәбәрсез юк булган Иргали ич... Күр инде, исән икән ләбаса, күптән җирләнгән чутында йөрткәләр иде ич үзен, – диде.* М.Хәсәнов. *Шул китүдән Мостафа эзсез-хәбәрсез юкка чыкты.* А.Әхмәтгалиева

**ЭЗТАБАР** *и.* **1.** 1) *к.* **эзкуар**

2) Хайваннарны эзләре буенча танып, таба алучы, эзеннән барып тотучы тәҗрибәле аучы

3) Сугышларда, тарихи вакыйгаларда батырлык эшләп тә исемнәре халыкка билгесез калганнарны табучы, алар турында мәгълүмат җыючы кеше. *Эзтабарлар сугышта катнашкан авылдашлары турында күп кенә материаллар җыйганнар.* М.Галиев. *Сугыш тәмамлангач, барып эзләп тә карадым, ләкин таба алмадым. Әгәр дә кызыл эзтабарлар белән бергәләшеп, күренекле галимнең каберен үзебез эзләп карасак?* Ф.Зыятдинов

**2.** *с. мәгъ.* Эз таба белгән; эз буенча эзләү өчен файдаланылган. *Памир – ярышларда катнашкан, ике медаль белән бүләкләнгән бозау хәтле нәселле эзтабар эт иде.* М.Насыйбуллин. *Әүвәлрәк эзтабар этләр --- Казан метрополитенын тикшерүгә әледән-әле чакырылса, хәзер ун эт биредә даими хезмәт итә.* Мәдәни җомга

**ЭЙ** *ы.* 1) Гадәттә ерактарак торган кемгәдер мөрәҗәгать иткәндә, эндәшкәндә, чакырганда кулланыла. *Строй белән барган диңгезчеләр аңа кычкыралар: – Эй, кореш!* М.Мәһдиев. *Кайда сез, эй, илне саклаучы баһадирлар?!* Р.Батулла

2) Берәрсен кисәткәндә кулланыла. *[Кәрим:] Эй, торма әле, үзең син ниерәк.* Г.Каюмов. *Эй, үкенерсең әле бездә калмавыңа.* А.Хәсәнов

3) Гаҗәпләнүне, таң калуны, соклануны белдерә. *Шул ике ярым-өч яшьләремдә төшкән фото сакланган, эй.* А.Хәсәнов. *Дөнья матур бит, эй!..* К.Кәримов. *Киенгәч-ясангач, тач апасына охшап калды бит бу, эй.* А.Тимергалин

4) Үкенүне, борчылуны яки искитмәүне белдерә. *– Эй, адәм рәтле сүз әйтә дип торабыз тагын, – дип көлешеп алдылар.* А.Алиш. *– Эй, мескеннәремне ничек кызганмаганнар! – дип көйләп әйтеп куйды.* А.Шамов

5) Кызгануны яки үтенүне белдерә. *--- сылу кыз чиксез кайгыга бата һәм теләк тели башлый: «Эй! Кош булып очып кына барсам иде яннарыңа!»* Дастан. *Кече якта кемдер көрсенеп куйды, кызганган тавыш: – Эй, бичара, нигә бу кадәр өзгәләнә, авылда кыз беткәнмени, – диде.* Г.Әпсәләмов. *Эй, мәрхүм Машкин! Ул безнең өлкән балабызга яшьтәш кенә иде шикелле. Бик яшьли дөньядан китте.* Ф.Чанышева

**ЭЙФОРИ́Я** *и. гр.* 1) *мед.* Организмның үз-үзен саклау реакциясе буларак рухның даими күтәренке халәте

2) Объектив шартларга туры килми торган күтәренке рух, шат күңел, канәгатьлек хисе; артык ваемсызлык, мәнсезлек. *Хыялыбызны гамәлләштерүдә эйфориягә бирелү куркынычы да бар.* Р.Сафин. *Шул саннар зурлыгыннан хозур алып, чабаталары сәләмә килеш тә бәхетле елмаерга мәҗбүр итеп, утызынчы елларда ялган эйфория тудырган шәхес турында мин унсигез яшемдә башкача уйлый идем әле.* М.Галиев

**ЭКВАДО́РЛЫ** *и.* Эквадорда яшәүче яки Эквадорда туган кеше. *«Рубин»ның 26 яшьлек эквадорлы ярымсакчысы Кристиан Нобоа Мәскәү «Динамо»сына күчәчәк.* Ирек мәйданы

**ЭКВА́ТОР** *и. лат. геогр.* 1) Җир шарын һәм күк сферасын көньяк һәм төньяк ярымшарларга бүлә торган уйланма сызык. *Әгәр шушы Күктау булмаса, Мәскәү дә, экватор да, котып та гап-гади географик төшенчәләр булып кына калырлар иде.* А.Гыйләҗев. *Кайдадыр экваторда кояш кыздыра, ябалдашларын киң җәеп, мәһабәт пальмалар үсеп утыра ---.* М.Хәбибуллин

2) *күч.* Чикләнгән вакыт эчендә төгәлләнәчәк эшнең эшләнгән яртысы, яртысының чиген үтү

**ЭКВАТОРИАЛ** *и. лат. астр.* Күк сферасындагы теләсә кайсы яктырткыч җисемнең күк экваторына карата торышын билгели торган линзалы яки көзгеле телескоп. *Астрономия дәресендә экваториал белән танышу*

**ЭКВАТОРИАЛЬ** *с. геогр.* 1) Экваторга якын, экватор тирәсендәге, экватордагы; шул тирәдә була торган, тропик. *Хәзерге вакытта ташбакаларның 250 гә якын төре билгеле. Алар тропик, экваториаль һәм урта пояста таралган.* Т.Шакирова. *Амазонка түбәнлеге эссе һәм дымлы экваториаль климат полосасында ята, анда еллык уртача температура (+25° ка җитә) айларга карап бөтенләй тирбәлми диярлек.* Чит илләрнең экономик географиясе

2) Африка, Көньяк һәм Көньяк-Көнчыгыш Азия, Океания һәм Австралиянең экваторга якын тропик зонасында таралган (раса тур.)

**ЭКВИВАЛЕНТ** *и. лат.* **1.** 1) *кит.* Берәр нәрсәгә һәр яктан тиңдәш, тәңгәл була алырлык икенче нәрсә. *Тик сез үзегез тәкъдим иткән лемма бишенче постулатка эквивалент булмасмы соң?* Җ.Тәрҗеманов. *--- тәңгәллекләр дигәндә, ике телдә һәрвакытта да, һәр очракта да эквивалентлар, тәңгәл берәмлекләр бар икән, дип уйларга ярамый.* Р.Юсупов

2) *хим.* Бер өлеш водород белән кушыла торган яки шушы өлешне аерым кушылмаларда алмаштыра торган элемент микъдары

3) *физ.* Механик һәм җылылык энергиясе берәмлекләренең үзара нисбәтен чагылдыра торган зурлык

4) *икъд.* Берәр товарның кыйммәтен билгели торган икенче бер товар. *Алыш-бирешнең сату-алуга, сәүдәгә әверелүенең төп билгесе буларак гомум эквивалент бәя формасы, ягъни акча барлыкка килә.* Ә.Мөхәммәдиев. *Нәкъ биш йөз долларга тигез эквивалент тоттырдым мин турфирма кешеләренә.* Я.Шәфыйков

**2.** *с. мәгъ.* Кайсыдыр яктан нәрсәнедер тулысынча алмаштыра алган, тигезкыйммәтле. *Гидроксидның эквивалент массасы металлның һәм гидроксид төркемнәренең эквивалент массалары суммасына, ә тозның эквивалент массасы металлның һәм анионның (кислота калдыгының) эквивалент массалары суммасына тигез.* Г.Хисамиев. *Конденсаторның эквивалент схемасы*

**ЭКВИВАЛЕНТЛЫ** *с. ялг. к.* **эквивалент 2.**

**ЭКВИВАЛЕНТЛЫК** *и. кит.* Тиңдәшлек, тулысы белән алмаштыра алучанлык. *«Мәгариф – Вакыт» нәшриятында дөнья күргән «Сайланма әсәрләр»ендә тәрҗемә мәсьәләсе, оригинал һәм тәрҗемә әсәрләренең эчтәлек гомумилеге, мәгънәви якынлыгы, ягъни эквивалентлыгы каралачак.* Фән-ни Татарстан. *Энергия эквивалентлыгы принцибын кулланып, И.Г. Терегулов юка кабырчыклар өчен билгеләүче нисбәтләр кертә.* Фән һәм тел

**ЭКВИЛИБРИСТ** *и. рус* 1) Эквилибристика белән шөгыльләнүче цирк артисты. *Әгәр дә составка чакырылган өч профессиональ артистны –эквилибрист Роза Хөсәенова, гимнаст Зинаида Васильева һәм палас шамакае Алик Низаметдиновларны – искә алмасак, татар цирк коллективы асылда әнә шул һәвәскәрләрдән туа.* Ш.Рахманкулов. *Аны 1949 елда тәмамлап, артист исеме алдым һәм Минзәлә театрында эквилибрист, иллюзионист булып эшли башладым.* Р.Гарифуллин

2) *күч.* Вазгыятькә оста җайлашучы, яраклашучы елгыр кеше

**ЭКВИЛИБРИ́СТИК** *с.* Эквилибристикага мөнәсәбәтле. *Куплярнең батырлыгы җитәр микән гомер буе мондый кыл өстендә эквилибристик --- уеннар уйнап яшәргә?!* Казан утлары

**ЭКВИЛИБРИ́СТИКА** *и. лат. махс.* 1) Тигезлек саклау осталыгына корылган катлаулы акробатик күнегүләр, хәрәкәтләр ясау сәнгате, шул сәнгатьнең цирк жанры. *Биредә балалар жонглёрлык, акробатика, гимнастика, эквилибристика, бию серләренә төшенәләр.* Сабантуй

2) *күч.* Вазгыятькә җайлашу, яраклашу

**ЭКВИЛИБРИСТЛА́РЧА** *рәв.* Эквилибристларга хас булганча. *Мин капкадан ат абзарына кадәр, эквилибристларча тигезлек саклап, койма буйлап узам, аннан кире кайтам.* Юлдаш

**ЭКГ** *и. кыск. рус мед. к.* **электрокардиограмма**. *Бу юлы дәвалаучы Роза Сәлихҗановна Аксёнова җентекләп тикшерде, кабат-кабат (көн дә!) ЭКГ ясап тора иде һәм миңа хәлнең бик җитди булуын --- әйтте.* Ф.Чанышева. *Рамил әфәнде төрле дарулар эчәргә киңәш итсә, Галина ханым, ЭКГ нәтиҗәләрен карап, хастаханәгә ятарга кушты.* Шәһри Казан

**Э́КЕР** *и. фр. геодез.* Җир өстендә $45^0$ яки $90^0$ зурлыктагы почмаклар үлчәп салу өчен кулланыла торган гади әсбап. *Аның артыннан Саша бара. Уң кулында өч аяклы экер, сулында – землемер чылбыры.* Җ.Тәрҗеманов

**ЭКЗАЛЬТА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Соклану, таң калу, шатлану белән бәйле ярсыну халәте. *Ул [Хәбир] әллә нинди экзальтациягә бирелеп, симфоник поэма язып ташлады.* Ш.Хөсәенов. *Олы шигъри талант иясе Ш. Зәки гадәти генә сүзләргә дә Аллага сыгынуларындагы экзальтациягә тиң эмоциональ бизәкле яңгыраш бирә.* Безнең мирас

2) Физиологиядә кыска вакытка тукыманың ярсынучанлыгы күтәрелү. *Мускул тукымасының экзальтациясе. Тоташтыргыч тукыманың экзальтациясе*

**ЭКЗАЛЬТА́ЦИЯЛЕ** *с. кит.* Экзальтация, чиксез шатлык белән сугарылган; экзальтация хәлендәге, экзальтация аркасында килеп чыккан. *Мистика, дини экзальтацияне хәтерләткән чалымнар актив файдаланылган очракта да аларның мистик яки экзальтацияле төсмерләре, әлеге сюжет тармаклан-дырулар – күчемлелекләр тәэсирендә гүя нейтральләштерелә.* М.Гайнетдин

**ЭКЗА́МЕН** *и. лат.* 1) Нинди дә булса укытылган фәнне үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү өчен үткәрелә торган сынау; имтихан. *Син аны белмисең әле, ул җәй буе шәһәрдә экзаменнар биреп йөрде.* Г.Әпсәләмов. *10 нчы классны бетергәч, аттестат алу өчен, Яңавылга 30 чакрым җәяү барып экзаменнар бирдек, чөнки безнең мәктәптә, чыгарылыш имтиханнарын алу өчен, югары белемле укытучыларның саны җитми иде.* Р.Миңнуллин

2) Тиешле рәсми хокуклар, дәрәҗә алыр өчен үтелә торган сынау; имтихан. *Озак та үтми, беренче класска экзаменнар тапшыргач та, Рәшит Ясәвиевич мондый зур һава лайнеры белән сул як штурвалдан идарә итүгә ирешә.* Р.Ибраһимов. *ГАИга экзаменны да дүрт тапкыр барып бирдең.* Аманулла

3) *күч.* Гомумән берәр җитди сынау, тикшерү. *Сезнең бүген киләчәгегез хәл ителә. Сез – булачак депутат, халык алдында экзамен тотачаксыз.* Мәдәни җомга

**ЭКЗАМЕНА́ТОР** *и. лат.* Имтихан алучы. *Студентның җавабын рухсыз гына тыңлыйсың. Йөзенә күтәрелеп карамыйсың, фәлән фәннән бишле алган, димәк, сәләтле. Теге «фәлән фән»нең экзаменаторы – кырыс хатын-кыз.* М.Мәһдиев. *Китәр алдыннан бер кыз әйтте: – Дүшәмбе көн башка экзаменатор булачак.* М.Юныс

**ЭКЗАРХ** *и. гр.* 1) *тар.* Борынгы Грециядә храм каршындагы жрецлар башлыгы

2) *тар.* Византия империясендә нинди дә булса бер өлкәнең император тарафыннан билгеләнгән җитәкчесе

3) Православиедә аерым бер өлкәнең дини башлыгы. *Батумда мөселманнар Грузия экзархына мөрәҗәгать итеп, үзләренә химая итүләрен телиләр...* Г.Исхакый. *--- узган гасырның 90 нчы елларында Украина бәйсезлек алгач, илнең ул чактагы экзархы митрополит Филарет Украина православие чиркәвенең Мәскәү патриархатыннан аерылуы --- турында белдергән иде.* Мәдәни җомга

**ЭКЗАРХАТ** *и. гр.* 1) Византиядә экзарх (*2 мәгъ.*) тарафыннан идарә ителгән административ-территориаль берәмлек

2) Экзарх вазифасы; бер кешенең шул вазифада тору вакыты

**ЭКЗЕКУ́ТОР** *и. лат. иск.* 1) Россиядә 1917 елга кадәр хөкүмәт учреждениеләрендә хуҗалык бүлеге мөдире

2) Тән җәзасы бирүче, экзекуция ясаучы. *Казан университетының патша раслаган уставында экзекутор, ягъни тән җәзасы бирүче кеше законлаштырылган була.* Эзләнүләр, уйланулар, табышлар

3) *күч.* Чамадан тыш кырыс, рәхимсез кеше. *Әлтафиның күзен кан баса: нинди әйбәт, чибәр кыз бу алгебра укытучысы, ә бит – экзекутор.* М.Мәһдиев

**ЭКЗЕКУ́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Тән җәзасы. *Әлеге «комбинат»тагы унлаган крематорий мичләренең бер генә сәгатькә дә сүнеп торганы булмагандыр. Анда, «фильтрация», «экзекуция», «ликвидация» дип, көненә берничәшәр йөз кешене юк итеп торалар иде.* М.Хәсәнов // Гомумән җәза. *Мине өйдәге экзекуцияләр дә чиркандыра башлады инде. Атнасына бер көн булса кирәк, Митяның тиктормас энесе Борис җәзаланырга тиеш иде.* А.Расих

2) *иск. кит.* Хөкем карарын үтәү (җәзалау, мөлкәтен сатып җибәрү һ.б.)

3) Массакүләм төстә, халыкның күз алдында җәзалау

4) *күч.* Рухи газап. *Әлтафиның кичә иртәдән бирле тәгам ризык капканы юк! Ә укытучы рәхимсез, ул һаман яздыра: «Сарык итен югач ---». Әлтафи өчен бу дәрес – экзекуция.* М.Мәһдиев

**ЭКЗЕ́МА** *и. гр. мед.* Иммун, эндокрин һ.б. тайпылышлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән, кабарчыклы, сыткылы, кычытулы, тире ялкынсынуыннан гыйбарәт йогышсыз авыру. *Халык телендә «утлы су» дип йөртелә торган «Мацеста» шифалы суыннан, югарыда аталган авырулардан тыш, псориаз, экзема, нейродерматит, ихтиоз кебек тире бозылуларына, ашказаны, эчәкләр борчуларына файдасын күрәләр.* Т.Нәҗмиев. *Кушма Штатлардан, Германиядән алынган хәбәрләр бүгенге көн балаларында нервылылык, стресс, гиперактивлык, ашау, йоклау авырулары, экзема, аллергия, астманың үсү дәрәҗәсе бик нык югарыга сикерүен күрсәтә.* М.Вәлиев

**ЭКЗЕМПЛЯР** *и. лат.* 1) Үзара охшаш, бериш әйберләрнең аерым нөсхәсе, данә (гадәттә кулъязма яки басылып чыккан текст тур.). *Немец дәфтәре битенә кулдан язылган бу газета нибары ике экземплярда ике атнага бер чыга ---.* Г.Әпсәләмов. *Ул бик бәхәсле әсәр иде: аны Ә.Еники, А.Расих, Я.Халитов укыды, журнал редакторы З.Нури тунады – ахырдан, хак сүз әйтер өчен, Шәмси абыйга бирделәр. Бу экземлярда – алтылап кешенең искәрмәләре.* М.Мәһдиев

2) Нинди дә булса берәр төрнең аерым вәкиле (хайваннар, үсемлекләр тур.). *Тамырларының һәм яфракларының төзелеше яхшырак булган экземплярлар, туфрактагы дымны яхшырак алып файдаланулары аркасында, чүл шартларын уңышлырак кичерәләр.* Дарвинизм нигезләре. *Су коңгызының сирәк экземплярлы*

3) *сөйл.* Сәер яки гайре табигый сыйфатлары белән башкалардан аерылып торган кеше. *Әкәмәт кеше мин. Дөньяда бердәнбер экземпляр.* Т.Миңнуллин. *Ачуланмыйм мин сиңа, сирәк экземпляр. Әгәр син шундук ризалашсаң, башкаларга охшар идең.* Н.Гыйматдинова. *Эре гәүдәле, «сызылып киткән кара мыеклы» бу ир-ат үзе бер гаҗәеп экземпляр иде.* Х.Ибраһим

**ЭКЗЕРСИС** *и. фр.* Балетта махсус күнекмәләр формалаштыру, классик бию техникасын камилләштерү өчен күнегүләр системасы // *иск.* Музыка, фехтование, вольтижировка һ.б.ш.да систематик рәвештә үтәлергә тиешле махсус күнегүләр

**ЭКЗИСТЕНЦИАЛИЗМ** *и. лат.* Көнбатыш Европада XX гасырның 20 нче елларында субъектив идеализмның бер төре буларак үсеш алган, һәрбер шәхеснең яшәве әһәмиятле, кичерешләре кабатланмас тәҗрибә буларак өйрәнелергә тиеш, дигән фикерне алга сөргән фәлсәфи агым. *Әлбәттә, экзистенциализм фәлсәфәсе, хыял турында сөйләгәндә дә, мәхәббәт, матурлык һәм хакыйкатьне аңлау ноктасында тукталып калмый, бәлки үлемгә кадәр барып җитә.* Гали Рәхим. *Модернизм исә рус һәм Европа әдәбиятларында символизм, импрессионизм, экзистенциализм, экспрессионизм һ.б. агымнар рәвешендә үсә.* Ә.Закирҗанов

**ЭКЗИСТЕНЦИАЛИСТ** *и. рус* Экзистенциализм тарафдары. *Хикәяләүче үзе – өч юлның да мәгънәсезлеген, файдасызлыгын аңлаган кеше, абсурд, мәгънәсез дөньяда яшәүче ялгызак, матурлыкны сарайларга ябып саклау мөмкин түгеллеккә төшенгән экзистенциалист.* Гали Рәхим

**ЭКЗО-** *гр.* Кушма сүзләрнең «тышкы», «тыштагы» мәгънәсен белдергән беренче кисәге

**ЭКЗОБИОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Космоста һәм башка планеталарда тере материя һәм органик матдәләрнең барлыкка килүен һәм үсешен өйрәнә торган фән; космик биологиянең бер тармагы. *Экзобиология белгече. Экзобиология фәне. Экзобиология дәресе*

**ЭКЗОГА́МИЯ** *и. гр. этн.* Үз кабиләсеннән, үз ыруыннан, үз социаль төркеменнән хатын алуны тыя торган йола. *Әмма телләрнең киң таралуына, бер-берсенә тәэсир итешүенә сәбәп булган факторларның берсе – борынгы ыругчылыкка хас булган экзогамия йоласы икәнлеге беленгән.* Р.Әхмәтьянов. *Экзогамия кагыйдәсе буенча, ирләр бары тик чит ырудагы хатын-кызга гына өйләнә алганнар.* Л.Җамалетдинов

**ЭКЗОТ** *и. гр.* 1) Бер зонадан климаты белән нык аерылып торган икенче зонага кеше тарафыннан китерелгән үсемлек яки хайван. *Көньяк Америка экзоты. Африкадан китерелгән экзотлар*

2) Мәчеләрнең селекция нәтиҗәсендә барлыкка килгән кыска йонлы бер токымы

3) Сәер нәрсәләр белән мавыгучы, экзотика яратучы кеше

**ЭКЗОТЕ́РИК** *с. кит.* Бөтен кешеләргә дә аңлаешлы, серле булмаган. *--- мәҗүси халыклардан башлап, дәүләт (милләт) дине (экзотерик рухият) белән беррәттән, яшерен фәлсәфә элитасы (бик азсанлы жрецлар) гына белгән башка дин дә яшәгән.* Р.Сафин. *Мәгърипнең экзотерик (матдәви), Шәрыкның эзотерик (илаһи) фәлсәфәсен үзләштердем.* И.Әмирханов

**ЭКЗОТЕ́РИКА** *и. гр.* Эзотерикага капма-каршы буларак, сер булмаган, киң катламнарга дигән дини яки фәлсәфи тәгълимат

**ЭКЗОТИЗМ** *и. гр. лингв.* Башка халык көнкүрешенә караган специфик әйберне яки күренешне белдерә торган алынма сүз. *Экзотизмның текстагы функцияләре*

**ЭКЗО́ТИК** *с.* 1) Ят, чит җирләргә хас булган; шул җирләрдә генә була торган; читтән кайтарылган; бик ерак, бик ят. *Өстәлдә болай да нинди генә экзотик җимешләр дә тәм-том юк ---!* З.Фәйзи. *Аннан соң Австрия һәр бамбук куагы артыннан чуар милли киемгә төренгән, кулына кылычбалык сөяге тоткан --- индеец, папуас килеп чыгу --- мөмкинлеге булган Ямайка, Мадагаскар, Мали кебек экзотик мәмләкәт түгел.* Т.Галиуллин

2) *күч.* Сәерлеге белән таң калдыра торган, гаҗәеп, әкәмәт. *Һәр секторга үзенә аерым бер төстәге мәрмәр вагы тутырылган һәм шомартып катырылган, сектор уртасында шул ук алтын сызыклардан үзенә генә хас экзотик чәчәк ясалган.* Р.Мирхәйдәров. *Шлемның түбәсе кылыч йөзенә охшаш, анда батырлык билгесе ролен үтәгән ат кылы яки экзотик каурый куела торган булган.* Сөембикә

**ЭКЗО́ТИКА** *и. гр.* 1) Чит һәм ерак илләргә (күбесенчә Көньяк-Көнчыгыш илләренә) хас булган, ләкин башка

ил кешесенә сәер, кызыклы булып күренгән реалияләр, әйберләр. *[Шәфикъ абый] аннары чаяннарның явызлыгына, арык суларының болганчыклыгына, тут җимешенең... гомумән, экзотикага күчте.* М.Маликова. *Кыргый атау үзе кечкенә генә булса да, анда күргән матурлык, экзотика, гыйбрәтле очрашу һәм вакыйгаларны сөйләп чыгу өчен байтак вакытлар кирәк булыр иде.* Р.Мөхәммәдиев

2) *күч.* Сәерлеге белән таң калдыра торган, гаҗәп нәрсә. *[Г.Ибраһимов хикәяләрендә] кабиләчелек талашлары, җәйләүләре --- безнең өчен яңа, ят булган экзотикалары белән күз алдына бастырылган казакъ хәяты да бар.* Г.Нигъмәти

**ЭКЗО́ТИКЛЫК** *и. гр.* Кайсыдыр сыйфаты белән экзотик булу, гаҗәплек. *Моданың экзотиклыгы. Пейзажның экзотиклыгы*

**ЭКИПАЖ** I *и. фр.* Пассажирлар утырып йөри торган сиртмәле арбаларның гомуми исеме. *Искәндәрнең кайтыр вакыты җитә башлагач, ул, бернигә җөмга элек, станциягә улына каршы барачак экипажны һәркөн үз кулыннан үткәреп, кучеры Миңлегалигә төрле әмерләр биреп [торды].* К.Тинчурин. *Башка тармакка караган предприятиеләр арасында поташ, аяк киеме, экипаж (рессорлы җиңел арба), мех әйберләр җитештерүче мануфактуралар үсешкә ирешә.* Татарстан тарихы

**ЭКИПАЖ** II *и. фр.* 1) Корабль, самолёт, танк һ.б.ш.ның командасы, хезмәт итүчеләр составы. *Экипаж җыелганчы, сәгать уникедә вахтага басучы матросларны һәм кочегарларны ашатып чыгарырга кирәк иде.* М.Юныс. *Безнең сугышчан экипаж, мәсәлән, кызларның «өзелеп сөям, сагынып көтәм» дигән һәр хатына җавап итеп, фашистларның бер «Тигр»ын яисә «Фердинанд»ын шартлатырга йөкләмә алды.* М.Маликова

2) Диңгез пехотасының ярда урнашкан, гадәттә флот командалары составын тулыландыру өчен хезмәт итә торган хәрби берәмлеге

**ЭКИПИРО́ВКА** *и. фр.* 1) Берәр эшчәнлек (сугыш, спорт, су астына төшү һ.б.ш.) алып бару һәм куркынычсызлык тәэмин итү өчен кирәк булган барлык корал, обмундирование һ.б.ш. кирәк-ярак. *Төн аралаш диярлек тревога буенча күтәрүләр, тулы экипировкада марш-ыргылышлар да булып тора.* Р.Могыйнов. *Аукционда үткән гасырның 1970–1989 елларындагы солдатлары кигән йөзләгән мең экипировка үрнәге: мамык курткалар, чалбарлар, --- кирза итекләр һәм ботинкалар, пилоткалар сатылачак.* Мәйдан

2) Шундый кирәк-ярак белән һәр яктан комплектлау, тәэмин итү эше

3) *күч.* Өс һәм аяк киеме һ.б.ш. *Урманга баруның үзенең экипировка тәртибе була. Безнең күрше Вәли картта ул болай: юкәдән матур итеп шакмаклап үрелгән сумка.* М.Мәһдиев. *Сириннең һәм иптәшләренең кесәсендә өр-яңа йөзлекләр шыгырдый иде. Һәм Сирин уку елын, үзе уйлаганча, шактый ук яхшы экипировка белән каршы алды.* Ф.Латыйпов

**ЭКЛЕКТИЗМ** *и. гр. кит.* 1) Бергә кушылуы мөмкин булмаган төрле идея юнәлешләрен, карашларын, теорияләрне, сәнгать элементларын ирекле рәвештә берләштерү күренеше; шундый алым. *Кызганычка каршы, «Чура батыр» дастанын тикшерергә алынган фольклорчылар, эклектизм юлына басып, әлеге текстның берьюлы ике өлешенә, ягъни ике версиясенә дә таяналар ---.* М.Бакиров

2) *архит.* Төрле стиль элементларын берләштерүдән барлыкка килгән үзенчәлекле стиль. *Эклектизм рухында төзелгән бина*

3) Каршылыклылык, эзлексезлек, принципсызлык. *Менә шуның өчен дә безнең театрда, алама күлмәккә ситсы кештәк куйгандай, берсе икенчесенә ябышмый торган нәрсәләр, эклектизм килеп чыгадыр.* Т.Гыйззәт. *Боларны язганда, сез үзегезнең дә «лирик»мы, түгелме икәнегезне уйлап үтсәгез, яхшы булыр иде. Фикерләрегез буталчык, эклектизм белән тулганнар.* Х.Туфан

**ЭКЛЕ́КТИК** I *и. гр. кит.* 1) Эклектизмны алга сөрүче, эклектизм тарафдары

2) Принципиаль җирлеге булмаган, капма-каршы карашларда торган кеше. *Бу галим чын эклектик икән. Сәясәтче эклектик булырга тиеш түгел*

**ЭКЛЕ́КТИК** II *с.* 1) Төрдәш булмаган, охшашлыклары булмаган элементлардан торган, эклектизм стилендәге. *Модернизмның эклектик характерда булуы әдәбиятта төрле мәдәниятләргә, иҗади стильләргә хас алымнарны беркетә, урнаштыра.* Д.Заһидуллина. *Бу бинаның эклектик формадагы бизәлешендә «мавритан» стиле өстенлек итә.* Казан утлары

2) *күч.* Эзлексез, өзек-төзек. *Ректорның шактый буталчык, эклектик чыгышыннан соң сайлау кәгазьләре таратыла.* Т.Галиуллин

**ЭКЛЕ́КТИКА** *и. гр.* Эклектизм нигезендә барлыкка килгән әсәр, стиль һ.б.ш. *Тормышта табигый рәвештә барлыкка килмәгән мондый күренешне гадәттә «эклектика» диеп атыйлар һәм күбрәк очракта «минус» тамгасы белән тамгалыйлар.* М.Вәлиев. *Эклектиканың диалектикага охшашлыгы формаль төстә генә.* К.Гыйззәтов

**ЭКЛЕКТИКЛЫК** *и. кит.* Эклектик булу хәле

**ЭКЛИ́ПТИКА** *и. гр. астр.* 1) Кояшның ел дәвамында күк сферасы буенча хәрәкәт итеп барлыкка китерә торган, әйләнә формасындагы юлы. *Күк сферасы әйләнгән чакта эклиптиканың горизонтка карата торышы өзлексез үзгәреп тора.* Астрономия. *Бүген Кояш, эклиптика буенча хәрәкәт итеп, күк экваторын кичте һәм төньяк күк ярымшарыннан көньякка күчте.* Туган як

2) Җирнең Кояш тирәли әйләнү орбитасының яссылыгы. *Планеталарның иң мөһим параметрларының берсе булып аларның экваториаль яссылык белән эклиптика арасындагы почмак тора.* Фән һәм тел

**ЭКОГЕНЕЗ** *и. гр.* Эволюция барышында тере организмнарның үзара һәм тирә-як мохит белән экологик мөнәсәбәтләренең үсеш процессы

**ЭКО́ЛОГ** *и. рус* Экология белгече. *Үләннәрне экологлар, табигатьне саклаучылар кайгырта.* М.Маликова. *Экологлар исә якындагы дистә елларда ук терек табигатьнең күп кенә төрләре юкка чыгачагын дәлилилләр.* Ф.Зариф

**ЭКОЛО́ГИК** *с.* Экологиягә караган, шуңа мөнәсәбәтле. *Кабан мисалында табигать тирәлегенең, бигрәк тә йомык экологик системаның, үзенә бик тә сизгер, сак мөнәсәбәт таләп итә торган чәрексез, нечкә организм булуы күренә.* Р.Мостафин. *Ә безнең системага караган даруханәләрдәге үләннәрне курыкмыйча файдаланып була: һәрберсе экологик контроль узган.* Сөембикә

**ЭКОЛО́ГИЯ** *и. гр.* 1) Тере организмнарның үзара һәм тирәлек белән мөнәсәбәтен өйрәнә торган фән. *Экология аерым затларны, бер төр затларыннан торган популяцияләрне, популяцияләрдән торган бергәлекләрне һәм алар яши торган тирәлекне үз эченә алган экосистемаларны өйрәнә.*

А.Низамов. *XX гасырда шушы проблемаларны җентекләп өйрәнү, аларны чишү юлларын ачыклау функцияләрен үзенә йөкләгән яңа тармак – экология фәне барлыкка килде.* К.Гыйззәтов

2) Экологик система, табигать

3) Кеше эшчәнлегенең табигатькә тәэсирен өйрәнү буенча практик чаралар һәм фәнни дисциплиналар комплексы. *Берләштерелгән экология хезмәтенә экологлар да, биологлар, медиклар, --- философлар да җәлеп ителә.* Р.Мостафин. *Соңгы вакытта Илүсә кебек экология белгечләренә авыл җирендәге җитәкчеләрнең дә бик җитди йомышы төшә башлады.* М.Маликова

4) *күч.* Нәрсәнең дә булса саф, чиста, беренчел хәлен сакларга тырышу, шуның турында кайгырту. *Язучылар союзы идарәсенең пленумында --- беренче көн тәртибе булып экология мәсьәләсе каралды. Шунда рухи экология турында да күп сөйләделәр.* Т.Миңнуллин. *Шигърият бакчасы пычранды. Бүгенге көндә «шигърият экологиясе» мәсьәләсе бөтен җитдилеге белән көн тәртибенә басты.* З.Мансуров

**ЭКОНОМ-** 1) Кушма сүзләрдә «экономик» мәгънәсендәге кисәк

2) Кушма сүзләрдә «очсыз, арзанлы» мәгънәсендәге беренче кисәк. *Эконом-класс билетлары. Эконом-маркет*

**ЭКОНОМ** *и. гр. иск.* 1) Хуҗалыкчыл кеше, матди сакчыл кеше

2) Хуҗалык эшләре мөдире, хуҗалык эшләре белән идарә итүче. *Бер шәкерт, казанда барысы өчен дә аш пешерү, хуҗалык эшләрен карау өчен, жирәбә белән эконом итеп сайлана.* Эзләнүләр, уйланулар, табышлар. *Шәһит Әхмәдиев эконом булып эшләде.* Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар

3) *иск. к.* **икътисадчы** (*1 мәгъ.*). *Рус булмаган өлкәләргә түрә буларак рус боярлары, окольничийлар (икенче дәрәҗәдәге боярлар), стольниклар (патшаның баш экономнары) --- җибәрелгән ---.* Г.Баттал. *--- мин, үз чиратымда, университет экзекуторыннан һәм студентлар белән эш итүче экономнан, һәркайсының үзенә кагылышлы гадәттән тыш вакыйгалар турында миңа җиткерүен таләп итеп, күрсәтмә бирергә кирәк таптым.* Эзләнүләр, уйланулар, табышлар

4) *сөйл.* Экономия, сакчыллык. *Эчмәсеннәр, аракыга эконом булсын, ди.* Ф.Садриев. *Дүрт кирпечне берсе өстенә берсен өясең, күз ачып йомганчы, эт ботын күтәргәнче, дүрт метрлы стена әзер. Беренчедән, растворга эконом, икенчедән, – кладчикларга.* Д.Салихов

**ЭКОНОМЕ́ТРИКА** *и. гр.* Икътисад белемендә икътисади мәсьәләләрне математик һәм статистик алымнар белән чишү юнәлеше. *Безнең Казан Федераль университеты фәннәр рейтингында сигез юнәлеш (лингвистика; --- экономика һәм эконометрика; физика һәм астрономия; химия) буенча беренче 500 леккә кергән.* Шәһри Казан

**ЭКОНОМЕ́ТРИЯ** *и. гр.* Икътисади мәсьәләләрне оптималь чишү өчен файдаланыла торган математик һәм статистик алымнар һәм методлар

**ЭКОНОМИЗМ** *и. рус* 1) XIX гасырның 90 нчы елларында рус социал-демократлары арасында барлыкка килгән оппортунистик агым. *Бу сәяси һәм идеологик яктан караганда чикләнгән тенденция марксизм фәнендә «экономизм» дип исемләнде.* К.Гыйззәтов

2) Социологиядә чынбарлыкның теләсә нинди социаль, сәяси яки мәдәни чагылышын, башка факторларны исәпкә алмыйча, икътисади базиска гына кайтарып калдырудан гыйбарәт агым. *Монда безнең, «нәсел-нәсәбен белми торган Иван»га ияреп, хәтерсезләнә баруыбыз, вульгар экономизм рухында алган сай тәрбиябез төп рольне уйнады: нәрсә тизрәк, ничек арзанрак, шуңа ябышабыз*, янәсе. Р.Вәлиев

**ЭКОНО́МИК** *с.* 1) Экономикага бәйле, икътисади. *Нэпман – 1921 елда яшь совет дәүләтенең социалистик экономикасын ныгыту максаты белән кертелгән яңа экономик политика вакытында хосусый хуҗалыкта җитештерү һәм сәүдә итү юлына баскан кеше.* Һ.Такташ. *Шагыйрьнең яңалыгы нииндидер яңа фикерләрне, яңа тәгълиматны үзләштерүгә генә кайтып калмый: ул чакта поэзия үсеше фәлсәфи яки экономик фәннәрнең үсешенә, аларның эчтәлегенә генә тиңләшер иде.* Н.Юзиев

2) Хуҗалыкны оештыруга бәйле булган. *Эшчеләр өчен оештырылган экономик мәктәптән тыш, мастерлар, бригадирлар, прорабларлар һәм инженерлар, техник работниклар өчен конкрет экономия түгәрәге ачылды.* М.Хәсәнов

3) Матди хәлгә бәйле булган. *Мин инде бирәдән торып конкрет киңәш бирә алмыйм. Болар барысы да акчага һәм экономик хәлегезгә бәйле бит, мөмкинлекләрегезгә карап хәл итәрсез.* Ф.Сафин. *Аларның язмасында саннар да, канатлы сүзләр дә, колхозның һәм колхозчыларның экономик хәлен күрсәтә торган фактлар да җитәрлек була.* В.Нуруллин

4) *тар.* Җәмгыятьтә иҗтимагый үсешнең бердәнбер көче икътисади факторлардан гыйбарәт, дип тарихи процессны берьяклы аңлата торган (агым, юнәлеш). *Экономик материализм*

5) *тар.* Россиядә 1764 елга кадәр чиркәүләр һәм монастырьлар кул астында булып, соңыннан дини эшләрнең экономия коллегиясе карамагына күчерелгән. *Экономик крестьяннар*

**ЭКОНО́МИКА** *и. гр.* 1) Билгеле бер иҗтимагый төзелешнең җитештерүче көчләре үсешенә тәңгәл килә торган җитештерү мөнәсәбәтләре җыелмасы; икътисад. *Бөтен класска бер генә дәреслек бар. Шуңа күрә теге-бу илнең халкы экономикасы турында мәгълүматларны хәтердән сөйләү бик авыр.* М.Мәһдиев. *Монополияләр капиталистик илләрнең экономикасында команда биеклекләрен алып торалар.* Политэкономия

2) Берәр хуҗалык тармагының эчке төзелеше һәм финанс-матди хәле. *Шәһәр экономикасы үсүгә, шактый дәрәҗәдә, табигый шартлар да йогынты ясый.* Р.Мостафин. *Сара апа шатлана, бу бик әһәмиятле ел, ди, --- безнең илдә һәрнәрсә сыйфатлы булачак, илнең экономикасында борылыш ясалачак, ди.* Г.Зәйнашева

3) Хуҗалык, аны алып бару ысуллары, анда барган процессларның закончалыклары, җитештерү һәм товар алмашу процессында кешеләр арасында туган мөнәсәбәтләр турындагы фән. *--- нәрсә ул хосусый милек, дигән сорауларга безнең экономика фәнендә төгәл җавап юк шикелле.* Т.Миңнуллин. *Халикъ төннәр буе экономика өйрәнә.* З.Гыйниятова

**ЭКОНОМИСТ** *и. рус* 1) Предприятиеләр, оешмалар һәм дәүләт органнарының хуҗалык эшчәнлеге мәсьәләләре буенча белеме булган дипломлы (яки аттестацияләнгән) белгеч. *Ләкин колхозның экономисты сөйли: – Полосалар буенда кар калын була.* М.Мәһдиев. *Үзегез беләсез: белемем буенча мин – тарихчы, ә Гадил Закирович – экономист.* М.Маликова

2) Предприятиеләрнең, оешмаларның хуҗалык-финанс эшчәнлегендәге хәле турында нәтиҗәләр ясаучы эксперт

3) Матди байлыклар җитештерүдә ресурслардан нәтиҗәле файдалану мәсьәләләрен өйрәнүче фәнни хезмәткәр. *Тарихчылар – җәмгыятьнең үткәнен, экономистлар – киләчәген әйтәләр.*

М.Мәһдиев. *Экономистлар исәпләвенчә, күлләр һәм алар тирәсендәге территорияләрне тулысынча реконструкцияләү --- йөз миллион сумга төшәчәк.* Р.Мостафин

4) Югары яки урта махсус белем бирә торган уку йортларында икътисад фәннәре укытучысы

5) *тар.* Экономизм тарафдары, экономизм идеяләрен хуплаучы. *«Экономистлар» --- эшчеләр сыйныфына аң кертү кирәклеген инкяр итәләр, социалистик идеология эшчеләрнең стихияле хәрәкәтеннән үзеннән-үзе килеп чыга, дип белдерәләр.* Татарстан тарихыннан хикәяләр

**ЭКОНО́МИЯ** *и. гр.* 1) Матди сакчыллык, исәпләп тоту, сакчыл булу гадәте; хуҗалыкны шулай алып бару ысулы. *Бозаулар өчен яңа торак салырга кирәк. --- Участоктагы экономия бәрабәренә бездән дә өлеш чыгарырга булыр.* А.Гыйләҗев

2) Берәр нәрсәне саклык белән тотудан алынган файда, тотылмыйча, сарыф ителмичә калган акча. *Ул [проект] әллә ни кыйбатка төшмәячәк. Монда зур мәйдан алынмый, урынны төзелешкә әзерләүдән шактый экономия булачак.* М.Маликова

3) *иск.* Алпавыт хуҗалыгы, утар. *Эре капиталистик экономияләр яллы эшчеләргә сорау тудыралар.* Политэкономия

4) Патша Россиясендә авыл хуҗалыгы эшләре белән идарә итә торган учреждение

5) Фикерне белдерүдә, сөйләмдә, язуда һ.б.ш.да кыскалыкка, аныклыкка, төгәллеккә омтылу күренеше, кыскарту. *Сөйләм энергиясе экономиясе законнары*

**ЭКОНО́МИЯЛӘҮ** *ф.* Нәрсәдән дә булса сакчыл файдалану, сак тотарга тырышу, әрәм-шәрәмгә юл куймау, экономия ясау. *Профессор хирургның кетгут экономияләвенә игътибар итә.* С.Сөләйманова. *Ничек кенә экономияләргә тырышсам да, әти белән әнинең чүгендер алган акчаларын һәммәсенә дә җиткереп булмады.* Аманулла. *Группадашлары кышкы сессиягә акча әзерли башлаганнар: эш тапканы эшкә урнашкан, кайсы яшәр өчен өйдән җибәрелгән акчаны экономияли.* Сөембикә

**Экономияләп карау** Экономияләргә тырышу

**Экономияли башлау** Экономияләргә тотыну. *Социологлар ачыклаганча, соңгы ярты елда сораштырылганнарның 39 проценты ризыкларда экономияли башлаган ---.* Шәһри Казан

**Экономияли төшү** Бераз экономияләү

**ЭКОНО́МИЯЛЕ** *с. гр.* 1) Нәрсәне дә булса исәпләп сак тотучан, сакчыл. *Аннан соң, бай булмасам да, бик экономияле кеше мин: кыш көне җыйган берничә тәңкә акча миңа җәйне буш үткәрергә мөмкинлек бирә.* Г.Рәхим. *Экономияле хуҗа*

2) Отышлы, файдалы, табышлы, нинди дә булса экономия бирә торган. *Империалистик милитаризмның һөҗүмчән хәрәкәте көчәйгән дәвердә һәр кеше «экономиканың экономияле булырга тиешлеген» аңлап яшәргә тиеш.* Т.Галиуллин. *Бөтен җирдә экономияле эшләү турында сүз бара.* Л.Ихсанова

**ЭКОНО́МИЯЛЕЛЕК** *и.* Сакчыллык. *Яңа двигатель экономиялелек, ышанычлылык, файдалы эш коэффициенты һәм экологик куркынычсызлык буенча югары характеристикага ия.* Татарстан. *Татарстан Республикасы Хисап палатасы бюджет чыгымнарының нәтиҗәлелеге һәм экономиялелегенә контрольлек итүне игътибар үзәгендә тота.* Ватаным Татарстан

**ЭКОНО́МКА** *и. рус* Бай гаиләдә хуҗалык эшләрен алып баручы хатынкыз; хуҗалык эшләре мөдире. *Әйбәт, чиста бүлмәләрдә торгач, син тагын эшчеләр, прислугалар, экономкалар асрап, бояр булып торалар дип уйлама.* Һ.Такташ. *Экономка үзенең бүлмәсенә чакыртып эчерә башлады.* А.Таһиров

**ЭКОСИСТЕ́МА** *и. рус* 1) Тере организмнар һәм аларның тору урыны белән бергә барлыкка килгән бербөтен табигый комплекс; экологик система. *Экология аерым затларны, бер төр затларыннан торган популяцияләрне, популяцияләрдән торган бергәлекләрне һәм алар яши торган тирәлекне үз эченә алган экосистемаларны өйрәнә.* А.Низамов. *Без монда формалашучы этносның үзе тирәсендәге экосистема белән тыгыз бәйләнешен күзәтәбез, бу, гадәттә, статистик үсешле этносларга хас.* Б.Хәмидуллин

2) *информ.* Бер җитештерүченең, бер ширкәтнең бер-берсенә яраша, туры килә торган информацион техника һәм программалары тәэминаты

**ЭКОСФЕ́РА** *и. рус* Кеше, хайваннар, үсемлекләр һәм әйләнә-тирә мохиттән, шуларның бергәлегеннән торган дөнья; экологик сфера; шул ук биосфера. *Җирнең экосферасы*

**ЭКОЦИД** *и. гр.-лат. махс.* Массалы рәвештә үсемлек яки хайван дөньясын юк итү, атмосфераны һәм су байлыкларын агулау һәм экологик һәлакәткә китерә торган башка шундый җинаятьләр

**ЭКРАН** *и. фр.* 1) Төрле энергия нурланышыннан файдалану яки аларның тәэсиреннән саклану өчен, шул нурланышны чагылдыра, йота һәм үзгәртә торган өслеге булган җайланма. *Бер киштәдән «Волхов» телевизорының күгелҗем экраны тонган күз кебек карап тора, аның астындагы киштәдә мандолина ята.* М.Мансурова. *Фотоаппаратта экран ролен үлчәме зур булмаган плёнка (яки пластинка) үти, шуңа күрә дә сурәт кечерәйтелгән булырга тиеш.* Физика

2) Кинокартина күрсәтелә торган ак тукыма яки башка материалдан эшләнгән пәрдә. *Тик шунысын автор белә алмады: Таныштылар микән урамда, Таныштылар микән зур бакчада, Ак экранда кино барганда.* Ш.Маннур. *Билетлар беренче рәткә генә калган иде. Хәер, Бакый экранга рәтләп карамады да, ул янәшәсендәге ак беретлы кызны күзәтеп утырды.* М.Маликова

3) Белдерү, хәбәр, мәгълүмат һ.б.ш.ны чагылдыра торган такта, щит, табло һ.б.ш. *Идарәдә һәм участокларда укуга йөреш һәм өлгереш экраннары булдырдык.* Р.Кәрами

4) *махс.* Нәрсәне дә булса кире кайтару, нәрсәдәндер саклау, киртәләү өчен хезмәт итә торган вертикаль яссылыклы җайланма; каплавыч. *Плотина экраны. Камин экраны*

5) *күч.* Кинотеатр. *Соңгы елларда җәмәгать урыннарында, сәхнәдән, мөнбәрләрдән, экраннардан, яңа ачылган радиолардан авыз тутырып, дөрес итеп ана телебездә сөйләгән кешеләрне ишеткәнем юк дияргә була.* Р. Батулла

6) *күч.* Кино сәнгате. *Экран хәбәрләре*

**ЭКРАНЛА́У** *ф. тех.* Көчле тышкы тәэсирләрдән саклау максаты белән экран кору, металл, кирпеч һ.б.ш. киртә, каплавыч белән ышыклау. *Приборны экранлау*

**ЭКРАНЛАШТЫРУ** *ф.* Кино чаралары белән башка сәнгать, гадәттә матур әдәбият әсәрләрен чагылдыру; шулар нигезендә кино яки телефильм төшерү. *Ул заманында татар сәхнәсендә байтак әсәрләре куелган, хәтта*

*«Койрыклы йолдыз» исемле сценариен экранлаштырган --- драматург Әхмәт Таҗетдин улы булырга тиеш.* А.Расих

**Экранлаштыра башлау** Экранлаштырырга керешү

**Экранлаштырып бару** Булган берсен рәттән экранлаштыру

**Экранлаштырып бетерү** Барысын да экранлаштыру

**Экранлаштырып килү** Күптәннән, эзлекле рәвештә экранлаштыру

**ЭКС-** *лат.* Кушма сүзләрнең берәр дәрәҗәне, вазифаны белдергән исем алдында килеп «элекке», «әүвәлге» мәгънәсен белдерә торган беренче кисәге: *экс-президент, экс-министр*

**ЭКСГА́УСТЕР** *и. лат. тех.* Предприятиеләрдә тузан, пар, газ һ.б.ш.ны суыргыч вентилятор. *Эксгаустерның сафтан чыгуы*

**ЭКСГУМА́ЦИЯ** *и. лат.* Суд медицинасы экспертизасы яки патологоанатом тикшерүе өчен, мәетне күмелгән урыныннан казып алу. *Эксгумация Казан мэры карары нигезендә һәм барлык санитария таләпләренә туры китереп башкарылды.* Татарстан яшьләре. *Шунда без мәетләргә эксгумация ясарга һәм аларны Штендальгә – безнең яңа штаб-квартирага күчерергә приказ алдык.* Юлдаш

**ЭКСГУМА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Эксгумация ясау, мәетне күмелгән урыныннан казып алу. *Мәмдүдә Тәфкилеваның мәетен эксгумацияләү анык нәтиҗә бирмәде. Беренче кат тикшерүдән үк күренгәнчә, ул агу-мазар эчеп үлмәгән, тәнендә күгәргән җир яки җәрәхәт эзләре дә юк.* А.Тимергалин. *Чистайда, судмедэкспертиза үткәрү өчен, 58 яшьлек пенсионер әбинең мәетен эксгумацияләгәннәр.* Шәһри Казан

**ЭКСИКА́ТОР** *и. лат. махс.* Көпшәк, дым тартучан матдәләрне билгеле дымлылыкта саклау яки әкрен киптерү өчен хезмәт иткән, герметик томалана торган калын пыяла савыт

**ЭКСКАВА́ТОР** *и. ингл.* 1) Җир казу, өю, төяү өчен кулланыла торган бер яки берничә чүмечле җир казу машинасы. *Куәтле зур экскаватор килә дә, шул күкрәп утырган ашлыкны икегә ярып, тирән канау казып китә.* А.Әхмәт. *Тынычлыкны бозып, тау буена экскаваторлар килгәннәр.* Ә.Ерикәй

2) *мед.* Организмдагы куышлыкларны кыру өчен кулланыла торган хирургия әсбабы. *Экскаваторны йогышсызландыру*

**ЭКСКАВА́ТОРЧЫ** *и.* Экскаваторда эшләүче. *Аптырашып торган экскаваторчыларга ташланырга телгән иде Гәрәй, тыйлыкты.* А.Гыйләҗев. *Ул фәкыйрь авылыңа кайтып нишләрсең, әйдә, минем абзый сине экскаваторчылар курсына урнаштыра ---.* М.Мәһдиев

**ЭКСКЛЮЗИВ** *с.* 1) Төрдәшләре булмаган, бердәнбер, кабатланмас. *Елена исә берара бик тә зәвыклы һәм эксклюзив модельләр тегәргә өйрәтүче тегү түгәрәгеннән кайтып кермәгән.* Асылъяр. *Былтыр Русиягә бик кыйбатлы эксклюзив 1,5 мең машина кайтартканнар.* Мәдәни җомга

2) Бары бер генә кешенеке яки бер генә коллективныкы булган. *Юк, бу аның югалган сәгате түгел, ләкин аның сүзләренчә, әнисе истәлегенә охшатып эшләгән эксклюзив сәгать иде.* Х.Ширмән. *Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, республика парламентына традицион юллама белән чыгыш ясар алдыннан, «Татмедиа» АҖ генераль директоры Андрей Кузьминга «Татар-информ» агентлыгы өчен эксклюзив интервью бирде.* Йолдыз

**ЭКСКРЕМЕНТ** *и. лат. махс.* Тере организм эшчәнлеге нәтиҗәсендә бүлеп чыгарыла торган тизәк, сидек, тире, соңгылык һ.б.ш. матдә, калдык, бүлендек. *Гадәттә, ул экскрементлар туфрак структурасына караганда бик каты булалар.* А.Фәткуллин. *Тәмәкечеләр өстенә ул чиләк белән су сибә, ә урамда этләренең нәҗесен җыймый калдырган хуҗаларына шул экскрементларны ыргыта.* Мәдәни җомга

**Э́КСКУРС** *и. лат. кит.* Төп темага бәйле булган нинди дә махсус мәсьәләгә кагылып үтү, аңлатып үтү; күзәтү. *Әйтерсең ул тарихның үзенә, җидесигез гасыр тирәнлеккә экскурс ясаган да күргәнен кешеләргә сөйли: менә, ди, тыңлагыз, безнең бабаларыбыз --- әнә шундый көй иҗат иткән.* М.Мәһдиев. *Үткәнгә экскурс рәвешендә аның биографиясе дә бирелә ---.* Н.Гыйззәтуллин

**ЭКСКУРСАНТ** *и. рус* Экскурсия төркемендә катнашучы. *Бу остаханәдә ел дәвамында меңләгән экскурсантлар була икән, Мәхмүт иң чибәр кызларның --- берничә чәч бөртеген кисеп алып кала икән.* М.Галиев

**ЭКСКУ́РСИЯ** *и. лат.* 1) Белем алу яки күңел ачу максаты белән күмәкләшеп берәр җиргә бару. *Тагын менә нәрсә: җәй көне күбрәк вакытыгызны ял итүгә бирегез – су керегез, балыкка йөрегез, берәр җиргә экскурсиягә барып кайтыгыз.* Г.Галиев. *Класс белән бергә музей, кино һәм театрларга, төрле-төрле экскурсияләргә йөрибез.* М.Насыйбуллин

2) Экскурсантлар төркеме. *Музей белән танышып чыкканнан соң, экскурсия кышкы сезонга репетицияләр ясау өстендә торган азәрбайҗан-төрек театрына керде.* Г.Кутуй

**ЭКСКУРСОВОД** *и. рус* Экскурсантларга карау өчен куелган экспонатларны, истәлекле урыннарны күрсәтеп, алар турында сөйләп, кирәкле аңлатмалар биреп йөрүче кеше. *Урамнарында әле бераз чирәм сакланган авылга килеп туктыйбыз. Мин – экскурсовод: – Менә, Сибгат абый, элеккеге байлар, сәүдәгәрләр авылы була бу.* М.Мәһдиев. *Экскурсовод яшь егетләрне-кызларны сәнгать музеена алып керә.* Н.Гыйматдинова

**ЭКСЛИ́БРИС** *и. лат.* Китап тышлыгының эчке ягына ябыштырыла яки мөһер белән сугыла торган китап хуҗасын раслау ярлыгы, билгесе. *Минем әтиемнән калган китапханәдә шундый бер китап бар: «Тормыш дәресе, яки Тәрбияле ата», 1915, Казан, «Милләт» китапханәсе. Менә шуның тышлыгында бер экслибрис минем игътибарымны җәлеп итте.* М.Мәһдиев. *Актарына торгач, кинәт китапның авантитулында таныш экслибрис күрдем: – Феликс, каян алдың син бу китапны?* М.Юныс

**ЭКСЛИБРИСИСТ** *и. рус* Экслибрислар җыю белән шөгыльләнүче. *Экслибрисистлар клубы*

**Э́КС-МИНИСТР** *и. лат.-фр.* Элеккеге министр. *Нәүзат бәй фикеренчә, партия юлбашчысы, ТКТҖ парламенты депутаты, министр һәм эксминистр, бизнесменнар белән очрашу минем өчен әһәмиятлерәк булырга, каләмемә күбрәк азык бирергә тиеш иде.* Т.Әйди

**ЭКСПАНСИВ** *с. кит.* 1) Үз-үзен, хисләрен, тойгыларын тыя алмый торган. *Экспансив холык*

2) Экспансиягә омтылучан, шундый үзенчәлектәге. *СССР таркалганнан соң, үзенең икътисади үсеше темпы, экспансив амбициясе һәм халык саны белән Кытай АКШның төп геостратегик көндәшенә әверелеп килә дияргә була.* Р.Сафин. *Мәскәү кенәзлегенең кинәт көчәеп китүе һәм аның экспансив*

*омтылышларының чиктән тыш активлашуы Казан ханлыгы чорында тынычлыкта яшәү мөмкинлеген чикләп торган.* Мирас

**ЭКСПАНСИВЛЫК** *и. кит.* Хистойгыларны тыя алмаучанлык. *Холыкның экспансивлыгы*

**ЭКСПАНСИОНИЗМ** *и. рус сәяси* Экспансия алып бару, дәүләт чикләрен һәм сату базарын көч белән киңәйтергә омтылу сәясәте. *Патша охранасы тюркизм идеяләрен агрессивлыкта һәм экспансионизмда гаепләп, аңа яла яга, абруен төшерә башлады.* М.Хәсәнов

**ЭКСПАНСИОНИСТ** *и. рус сәяси* Экспансияне яклаучы кеше, экспансионизм тарафдары

**ЭКСПА́НСИЯ** *и. лат.* 1) *сәяси* Яңа җирләрне һәм сату базарын көч белән басып алу максаты белән бер дәүләтнең башка дәүләтләргә икътисади һәм сәяси йогынтысын киңәйтү омтылышы, агрессив сәясәте. *Төркиләр күрше дәүләтләр экспансиясеннән һәм агрессиясеннән саклана.* Г.Фәйзрахманов. *Германия экспансиясе Ерак Көнчыгышка да тарала.* Яңа тарих

2) *кит.* Нәрсәне дә булса элекке чигеннән артыграк җәелдерү, артык актив рәвештә, көчләп киңәйтү. *АКШ монополияләренең экономик экспансиясе илләр арасында тарихи урнашкан күп яклы экономик элемтәне өзүгә алып бара.* Политэкономия. *Көнбатыш илләр колониаль изүдән күптән түгел азат ителгән һәм әле үзләренең бәйсез массакүләм информация чараларын оештыра алмаган илләрдә көчле идеология экспансиясе үткәрүне дәвам итәләр.* Казан утлары

**ЭКСПАТРИАНТ** *и. лат. сәяси* Экспатриациягә дучар булган кеше

**ЭКСПАТРИА́ЦИЯ** *и. лат. сәяси* Гражданлык хокукларыннан мәхрүм ителеп ватаннан сөрелү яки үз ихтыяры белән гражданлыктан баш тартып ватаныннан китү

**ЭКСПАТРИА́ЦИЯЛӘҮ** *ф. сәяси* Ватаннан сөрү

**Экспатриацияләп тору** Озак вакыт дәвамында даими рәвештә яки әледәнәле экспатриацияләү

**ЭКСПЕДИ́ТОР** *и. лат.* 1) Йөкне озатып йөрүче, тапшыручы, йөкләр алганда һәм җибәргәндә транспорт документларын тутыручы кеше. *Һәркайсы үз эше белән мәшгуль: итче ит чаба, экспедитор, машина янына басып, йөкчеләр эшен күзәтә.* З.Фәйзи. *Тимерханның байтак еллар элек кайсыдыр бер оешмада экспедитор булып йөргәнен --- Наилә сөйләгән дә иде бугай.* А.Гыйләҗев

2) *тар.* Патша Россиясендә кайбер учреждениеләрдә чиновник, бүлек мөдире

**ЭКСПЕДИ́ТОРЛЫК** *и.* Экспедитор вазифасы, экспедитор эше. *Г.Тукай Г.Дәүләтшинның «Китаб» нәшриятында экспедиторлык һәм корректорлык эшен дәвам иттерә.* Казан утлары

**ЭКСПЕДИЦИОН** *с.* Экспедициягә мөнәсәбәтле, экспедиция белән бәйле булган, экспедиция өчен билгеләнгән, экспедиция максаты белән оештырылган. *Сорау алудан килеп чыккан материал нигезендә экспедицион отрядлар төзелә.* З.Зәйнуллин. --- *күп еллар буе алып барылган экспедицион тикшеренүләр --- халык җырларын өйрәнүнең тагын да актуальләшүенә --- булышлык итте.* К.Миңнуллин. *Экспедицион склад. Экспедицион сектор*

**ЭКСПЕДИ́ЦИЯ** *и. лат.* 1) *махс.* Йөкләрне, почтаны һ.б.ш.ны кабул итү, тиешле урынына җибәрү, тарату, озату эше

2) Нәрсәне дә булса (йөкләрне, почтаны һ.б.ш.) кабул итү, тиешле урынына җибәреп, озатып тору учреждениесе яки бүлеге. *Экспедиция хезмәтенә газета артыграк бастырып бирелә, бу – алайболай подписчикларга газета җитмәгән очраклар өчен.* Файдалы киңәшләр. *Цехның әзер детальләр экспедициясе. Почтамтның газеталар экспедициясе*

3) 1917 елга кадәрге нинди дә булса дәүләт учреждениесе канцеляриясендәге бүлек. *Экспедицияләр Пугачёв восстаниесе вакытында утарлары һәм заводлары таланган дворяннарга һәм промышленникларга бурычка акча – ссуда бирергә тиеш була.* Татарстан тарихы. *Гәрчә 1,5 миллион сум зыян күрүчеләрнең ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен җитәрлек булмаса да һәм банк экспедициясе хезмәтеннән бары тик 248 кеше генә файдаланса да, ссуда күп кенә промышленность әһелләренә --- ярдәм итә.* Россия тарихы

4) Бер төркем кеше, отряд һ.б.ш.ның билгеле бер максат белән махсус оештырылган сәфәре, сәяхәте. *Студентлар белән ерак өлкәләргә фольклор җыю экспедицияләренә йөргәндә, без моны «саву» дип атыйбыз.* М.Мәһдиев. *XV гасырда европалылар, алтын эзләп, билгесез ерак илләргә экспедицияләр оештыра башлыйлар.* Урта гасырлар тарихы

5) Шундый сәфәргә, сәяхәткә чыккан кешеләр төркеме, отряды. *XV гасыр башыннан алып, Португалия корольләре Африканың көнбатыш ярлары буйлап Атлантик океанга даими рәвештә экспедицияләр җибәреп торалар.* Урта гасырлар тарихы. *Россия Гуманитар фәннәр һәм Татарстан Фәннәр академиясенең Тарих институты планы нигезендә тарих-археология экспедициясе Әстерхан өлкәсендә булып кайтты.* Сөембикә

6) Икенче бер илдә үткәрелгән (гадәттә махсус частьләр тарафыннан) хәрби акция, операция, сугышчан хәрәкәтләр. *Роммельнең Африка экспедициясе*

**ЭКСПЕДИ́ЦИЯЧЕ** *и.* Экспедиция (*5 мәгъ.*) әгъзасы, экспедициядә катнашучы. *Экспедициячеләр әле кайтмаган иде.* Г.Ахунов. *Эзләнүләр тагын дәвам итә, һәм экспедициячеләр тагын күп кенә кызыклы әйберләргә юлыгалар.* А.Муранов

**ЭКСПЕРИМЕНТ** *и. лат.* 1) Фәнни тәҗрибә. *Мөдир --- эксперимент төгәлләнгән, хәтта ачыш ясалган дип исәпли.* Ә.Баян. *Югыйсә параллель класс, бер программа белән укыйбыз, --- бер хезмәт урынында эшләп өйрәтәбез. Безнең бу рәвештә шундый программа белән уку Казанда беренче эксперимент булмады микән әле?* А.Расих

2) Берәр эш эшләргә омтылып карау; нәрсәне дә булса берәр юл белән тормышка ашыруны сынау; гомумән тәҗрибә. *Бакчада әтинең малайларча эксперимент уздыра торган гадәте дә бар иде. Мәсәлән, үсеп килгән кабакка ул бервакыт, тырнап, үзенең исемен язып куйган.* М.Мәһдиев. *Ә менә Туймазы театры экспериментлар ясаудан курыкмый.* Сөембикә

**ЭКСПЕРИМЕНТАЛЬ** *с.* 1) Эксперимент буларак башкарылган, экспериментка бәйле. *Заводта эксперименталь өйрәнчеклек ФЗӨ мәктәбе ачыла икән.* А.Расих. *Латин графикасына күчү буенча эксперименталь мәктәпләр, сыйныфлар эшләде*. Р.Вәлиев. *Диссертациянең эксперименталь өлеше* // Тәҗрибә, эксперимент өчен ясалган. *Эксперименталь трактор*

2) Экспериментлар үткәрү белән шөгыльләнгән. *Ә мин эксперименталь цехта эшләячәкмен. Наилә Хәбировна шулай диде.* А.Вергазов. *Сүз уңаенда гына, Мәскәүдә укып диссертация язганда, эксперименталь база итеп, Балтач – Кукмара районнары мәктәпләрен алдым.* М.Әхмәтҗанов

3) Эксперимент ысулын куллануга нигезләнгән. *Эксперименталь мәгълүматларга нигезләнеп, татар авазлары чуваш, хакас, казах һәм башка телләрнең авазлары белән чагыштырыла.* Татар грамматикасы. *В.А. Богородицкий телебезнең эксперименталь фонетикасына (телнең авазлар төзелешен өйрәтүче фән) нигез сала.* Татарстан тарихы

**ЭКСПЕРИМЕНТАТИВ** *с. к.* **экспериментальʹ**. *XX гасыр ахырында АКШта экспериментатив педагогика нигезендә педагогика барлыкка килә.* Ә.Хуҗиәхмәтов

**ЭКСПЕРИМЕНТА́ТОР** *и. рус к.* **экспериментчы**. *Инде үсеп җиткән экспериментатор булган вакытта, Иван Владимировичның язу кенәгәләрендә --- Ерак Көнчыгышта үсә торган чәнечкеле чияләр очрый.* А.Бахарев, П.Яковлев. *Тәҗрибәдә экспериментатор һәм тикшерелә торган кеше катнаша, алар рольләрен алмаша алалар.* Кызыклы психология

**ЭКСПЕРИМЕНТЧЫ** *и.* Фәнни тәҗрибә ясаучы, тәҗрибәче. *Китерелгән мисаллар экспериментчы Вәлиев-Сульваны кызыксындырган өлкәләрнең киңлеген һәм төрлелеген күрсәтә ---.* М.Арсланов. *Агарынды, кабаланды хуҗа шулчак – Синең сүзләр, Илдар абый, булып пычак, Кадалды экспериментчы күзенә...* Р.Миңнуллин

**ЭКСПЕРТ** *и. лат.* Экспертиза үткәрүче белгеч. – *Хәзер сүз Пахомов мәетен өйрәнгән экспертка бирелә, – диде тикшерүче, врачка таба борылып.* М.Насыйбуллин. *М.Шәймиев белдерүенчә, РФ Дәүләт Президиумының беренче утырышыннан соң, концепция өчен материалларны гомумиләштерәчәк көчле эксперт төркеме оештырылган.* Ватаным Татарстан

**ЭКСПЕРТИ́ЗА** *и. лат.* Нинди дә булса гамәли сорауга җавап бирү өчен, фән, техника, сәнгать һ.б.ш. тармакларга караган белемгә таянып берәр фактны яки предметны тикшерү. --- *ул [Волыкин] акылдан язган кеше булып кыланды. Судпсихиатрия экспертизасы моның ялган икәнен --- анықлады.* М.Насыйбуллин. *Мин иң элек медицина экспертизасы нәтиҗәләре белән таныштырам ---.* С.Зыялы

**ЭКСПЕРТЛА́РЧА** *рәв.* Экспертларга хас рәвештә, белгечләрчә төгәллек белән. *Кәгазьне ул экспертларча саклык белән өстәл өстенә җәйде.* Ф.Яруллин. *Даниэль Соломонович келдәгән тавышка гаҗәпләнеп идәнгә карады һәм төймәне иелеп алып, аны тәрәзәгә таба сузып, экспертларча күздән үткәрде.* Т.Әйди

**ЭКСПЛАНТА́ЦИЯ** *и. лат. махс.* Хайваннарның һәм үсемлекләрнең күзәнәкләрен, тукымаларын, органнарын махсус матдә, ясалма тирәлек эчендә озак вакыт саклау һәм үстерү

**ЭКСПЛИКА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Карталарда, планнарда кулланылган шартлы билгеләрнең аңлатмалары; легенда

2) Берәр нәрсәнең тасвирламасы, бәяләмәсе, аңлатмасы, файдалану кагыйдәләре һ.б.ш. бирелгән кыскача язма белешмә. *Күргәзмә экспонатларының экспликациясе*

3) *театр.* Спектакльнең (драма, опера, балет) режиссёр тарафыннан төзелгән, сәхнәләштерү, бизәлеш һ.б.ш. турында күрсәтмәләре булган язмача планы. *Режиссёрның экспликациясе бар нәрсәне хәл итә бу очракта.* Сәхнә

**ЭКСПЛУАТА́ТОР** *и. фр.* **1.** 1) Кеше хезмәтенең нәтиҗәсен үзләштерүче, изүче, җәберләүче. *Ләкин революция җәелгән һәм күтәрелгән саен, эксплуататорлар белән хезмәт ияләре арасындагы каршылык тирәнрәк ачылды.* М.Җәлил. *Политикада байларның барысының да бәясе бертөрле – эксплуататор!* Г.Бәширов

2) Үз мәнфәгатьләреннән чыгып кеше көченнән файдаланучы

**2.** *с. мәгъ.* Эксплуатациягә дучар иткән, изгән. *Совет властеның беренче елларында шәһәрдә һәм авылда эксплуататор сыйныф калдыклары советларга каршы саботаж, спекуляция һәм башка юллар белән көрәш алып баралар.* М.Җәлил. *Дөрес, Ленинның эксплуататор сыйныфларны дошман күрүе берәүгә дә сер түгел.* Ә.Еники

**ЭКСПЛУАТА́ТОРЛЫК** *и.* Эксплуататор булу. *Дөрес, бай хуҗаның эксплуататорлык сыйфатын кистереп инкарь итеп булмый торгандыр.* Ф.Ибраһимова. *Г.Тукайның эксплуататорлык җәмгыятен тәнкыйть утына тотуы – үзмаксат түгел, бәлки халыкны үзе яши торган шартларга төшендерү чарасы ---.* Ф.Әгъзамов

**ЭКСПЛУАТАЦИОН** *с.* Эксплуатациягә (*2 мәгъ.*) кагылышлы булган. *Әгәр дә машина (деталь) бирелгән вакыт дәвамында, билгеләнгән чикләрдә, сайланган режимнарда файдалану, техник хезмәт күрсәтү, ремонтлау, саклау, күчерү шартларында тиешле эксплуатацион күрсәткечләрне үти алса, аны ышанычлы дип саныйлар.* Фән һәм тел. *Скважиналарны бораулауга килгәндә, соңгы елларда эксплуатацион скважиналарны төзүдә чыгымнарны киметү юнәлешендә алга китү күзәтелә.* Заман сулышы

**ЭКСПЛУАТА́ЦИЯ** *и. фр.* 1) Җитештерү средстволары хуҗасының кеше хезмәтен үзләштерүе; гомумән, кеше хезмәтеннән файдалану, табыш алу. *Хезмәт ияләрен аяусыз изүгә – эксплуатациягә нигезләнгән капиталистик система эшчеләр һәм ярлылар сыйныфыннан исәпсез күп корбаннар чыгарып ташлый.* М.Җәлил. *Феодаль эксплуатациянең көчәюе, ярлыларга каршы рәхимсез законнар һәм салымнарның артуы халыкның ачуын чыгара.* Урта гасырлар тарихы

2) Табигый байлыкларны эшкәртү һәм алардан файдалану; җир, завод-фабрика, транспорт чараларыннан, биналардан һ.б.ш. системалы файдалану. *Шушы көннәрдә автотранспорт хуҗалыгының эксплуатация бүлеге эшчесе Бану Афзалова дигән хатынны пенсиягә озаткannar иде.* М.Хәсәнов. *Алар яңа шахтаны эксплуатациягә бирәләр.* А.Шамов

**ЭКСПЛУАТА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* 1) Эксплуатациягә дучар итү, кеше хезмәтен үзләштерү; изү, җәберләү. *Сәгыйть бабайның идеясе дә Кәрим байныкы кебек үк: мал җыю, баю, кеше көчен эксплуатацияләү.* М.Галәү. *Табигый ресурслардан файдалану һәм җирле халыкны эксплуатацияләү АКШ һәм Англиянең капиталистик монополияләренә бик күп доход китерә.* Чит илләрнең экономик географиясе

2) Табигый байлыкларны эшкәртү, җир, завод-фабрика һ.б.ш.дан тиешенчә файдалану. *Системаның бер генә кимчелеге бар: эксплуатацияләү кыйммәткә төшә, болай да исәпле электр энергиясе гаять күп тотыла.* Р.Мостафин. --- *идарәдә магистраль газүткәргечләрне техник эксплуатацияләү кагыйдәләре төгәл үтәлә.* Т.Нәҗмиев

**Эксплуатацияләп тору** Озак вакытлар буе эксплуатацияләү

**Эксплуатацияли башлау** Эксплуатацияләүгә керешү. *Ә полигонны эксплуатацияли башлаганнан бирле, ягъни 2000 елдан алып 2018 елга кадәрге чорда, полигонга 131920 кубометр күләмендә көнкүреш калдыклары чыгарылды.* Туган як

**ЭКСПОЗИ́МЕТР** *и. лат. иск. к.* **экспонометр**

**ЭКСПОЗИЦИОН** *с.* 1) Экспозиция булып саналган, экспозиция булып хезмәт иткән. *Күктә яңа туган Ай – һилал йөзә. Фильмның экспозицион өлеше әнә шулай вәгъдәле башлана: бу фильм – сабак, бу фильм – сагыш, бу фильм – гыйбрәт.* Р.Батулла

2) Экспозиция өчен билгеләнгән. *Экспозицион стенд. Экспозицион зал*

**ЭКСПОЗИ́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Музей, күргәзмә кебекләрдә сәнгать әсәрләре, тарихи материаллар һ.б.ш.ның тезелү, куелу рәвеше, билгеле бер системасы; шул предметларның барлыгы. *Күргәзмәләрдә шагыйрьнең төрле телләрдә басылган күпсанлы әсәрләре, документлар һәм материаллар экспозицияләре бөек Кобзарьның тормышы, күпкырлы иҗаты турында сөйлиләр.* Җ.Рәхимов. *Шулай да әлеге шәхси күргәзмәсен [Мусин] аеруча җаваплылык белән, дулкынланып әзерләде, экспозицияне кат-кат үзгәртте ---.* Т.Таһиров

2) Әдәби яки музыкаль әсәрнең соңга таба үстерелә барган мотивларны эченә алган кереш өлеше. *Хөкемдар һәм шагыйрь эш-гамәленә бәйле төп идеяне аңлауда хан белән шагыйрьнең беренче күренештә очрашуы – экспозиция һәм соңгы өлештә – эпилогта – теге дөньяда Бирдебәк белән Әхмәдинең көрешүе мөһим урын алып тора.* Ә.Закирҗанов. *Сюжетның экспозиция өлешендә укучы һәм тамашачы төп «каһарманнар» белән танышa, баш каһарманның асыл теләген белә.* Әдәбият

3) *махс.* Фотога, кинога төшергәндә, яктыга сизгер материалга төшкән яктылык энергиясен күрсәтә торган зурлык. *Вентильле фотоэлементларны фотоэкспонометрда экспозиция вакытын билгеләү өчен дә кулланалар.* Р.Шаһморатова. *Озак экспозиция белән төшерү*

**ЭКСПОНАТ** *и. лат.* Музей, күргәзмә һ.б.ш. урынга күрсәтер өчен куелган әйбер. *Данәгөл, кулына кечерәк кенә сумка тотып, аны җиңелчә генә изәп, залдагы экспонатлар белән танышып йөрде.* А.Хәсәнов. *Бөтен Советлар Союзы халыклары сокланып карыйлар бит күргәзмәдәге безнең экспонатларны.* Г.Галиев

**ЭКСПОНЕНТ** *и. лат.* Күргәзмәгә экспонат куючы кеше яки оешма. *Моңа кадәрге күргәзмәдә дөньяның 40 иленнән 500 ләп экспонент җыелган иде.* Мәйдан

**ЭКСПОНО́МЕТР** *и. лат.* Фотога һәм кинога төшергәндә экспозицияне (*3 мәгъ.*) билгели торган җайланма (яктыртылуны үлчәү приборы). *Икенче як җилкәдә фотоаппарат та бар. Аңа экспонометр асылган. Фотога төшерергә Зиннур бик ярата.* М.Мәһдиев

**Э́КСПОРТ** *и. лат.* 1) Табыш алу максатында сату яки файдалану өчен, чит илләргә товар, чимал, технологияләр һәм капитал чыгару; *киресе:* **импорт**. – *Машинаңны без алабыз, безгә бик тә ошады, мөгаен, экспортка – чит ил өчен эшләнгән булгандыр, – диде аларның берсе.* Р.Мирхәйдәров. – *Тиздән Уренгой–Помары–Ужгород экспорт газүткәргеченең шушы төбәгендә бик талаулы эш башланачак, – дип сөйләп китте ул.* М.Хәсәнов

2) Чит илгә чыгарыла торган товарның, капиталның гомуми күләме яки кыйммәте; шулай ук чыгарылган товарның, капиталның үзе. *Ил бюджеты керемнәренең нигезен билгеләүче нефть һәм газга экспорт пошлиналарын киметү яки бетерүнең нәрсәгә китерәсен әлегә бик кузгатырга теләмиләр.* Шәһри Казан

3) *информ.* Бер программа форматында төзелгән файлны компьютерның икенче программасына хас форматка күчерү

**ЭКСПОРТЁР** *и. фр.* Экспорт белән шөгыльләнүче физик яки юридик зат

**Э́КСПОРТЛАУ** *ф.* Чит илгә товар, капитал чыгару. *XIX гасырда Иван-чәйне рус сәүдәгәрләре Европага экспортлаган, һәм ул югары бәяләнгән.* Акчарлак

**Экспортлап килү** Элек-электән, күптәннән экспортлау

**Экспортлый башлау** Эспортларга тотыну. *Аерым ризыкларны Русия хәтта үзе экспортлый башлады.* Кызыл таң

**ЭКС-ПРЕЗИДЕНТ** *и. лат.* Элекке президент. *Президент һәм экс-президент, котлары очып, йөгереп аска төштеләр, ләкин анда инде пыяла кисәкләре, шөрепләр, стрелкалар һәм башка төрле кыйпылчыклар гына ята иде.* И.Хуҗин. *Бу эшләрнең дилбегәсен экс-президент М.Шәймиев үз кулына алды.* Казан утлары

**ЭКСПРЕСС** *и. лат.* Бары эре станцияләрдә генә тукталыш ясап, тиз йөри торган поезд, судно, автобус һ.б. *Гаҗәп бит бер уйласаң: самолёт, экспресс, тагын шуңа ике чакрым җәяү үтүне дә кушсаң, мең чакрымнан артык юл – берничә сәгать эчендә икесе ике параллельдә.* М.Галиев. *[Рушан] пассажир поездының соңгы вагоны артындагы сигнал утларын бик яхшы күреп алды – экспресс кузгалган гына иде әле.* Р.Мирхәйдәров

**ЭКСПРЕСС-** *лат.* Кушма сүзләрдә «тиз, тизләтелгән», «кыска вакыт эчендә» дигән мәгънәне белдерә торган беренче кисәк, мәсәлән: *экспресс-диагностика, экспресс-почта, экспресс-ысул* һ.б.

**ЭКСПРЕСС-ДИАГНО́СТИКА** *и. лат.-гр.* 1) Ашыгыч диагностика ысуллары һәм әсбаплары ярдәмендә авыруның үзенчәлекләрен ачыклау, диагноз кую. *Бу компания молекуляр-күзәнәк тераностикасы һәм онкологиядә экспресс-диагностика системалары өчен бионанороботлар эшләү белән шөгыльләнә.* Мәйдан. *Теләүчеләргә, ВИЧ статусын билгеләү өчен, экспресс-диагностика үтү мөмкинлеге дә бар иде.* Чистай хәбәрләре

2) Кыска вакыт эчендә махсус әсбаплар ярдәмендә машиналарның техник хәлен билгеләү, ачыклау. *Автобусларга экспресс-диагностика үткәрү*

**ЭКСПРЕССИВ** *с. к.* **экспрессияле**. *Атилла Расих та шулай каты «тондырды»: – Сездә Кави абый стиле сизелә, экспрессив стиль, – диде.* М.Мәһдиев. *Гуманистик шигырьләр. Бөтен сүзләрен аңлап бетереп булмаса да, шигырьнең рухын, эчке экспрессив көчен тоеп утырасың.* Р.Фәйзуллин

**ЭКСПРЕССИВЛЫК** *и. к.* **экспрессиялелек**. *Комик шигырьләрдә экспрессивлык тудыру өчен, әллә ни купшы сүзләр дә кирәкми икән югыйсә.* Ш.Галиев. *Сәгыйть Рәмиев эшкә керешүгә, лиризмга бай, эмоциональ, экспрессивлыгы көчле, шәхес проблемаларын күтәргән әсәрләр күпләп басыла башлый.* Ф.Җәүһәрова

**ЭКСПРЕССИОНИЗМ** *и. фр.* XX гасыр башында Европа сәнгатендә һәм әдәбиятында барлыкка килгән, рәссамның, әдипнең эчке дөньясын, шәхси иҗади кичерешләрен чагылдырудан гыйбарәт булган, берничә идеологик тенденцияне берләштергән юнәлеш. *Ләкин монда җыелган әсәрләрнең импрессионизм һәм экспрессионизмның туган вакытларындагы --- башлангыч әсәрләр икәнен игътибарга алырга кирәк.* Г.Гобәй. *Модернизм исә рус һәм Европа әдәбиятларында символизм, импрессионизм, экзистенциализм, экспрессионизм һ.б. агымнар рәвешендә үсә.* Ә.Закирҗанов

**ЭКСПРЕССИОНИСТ** *и. фр.* Экспрессионизм тарафдары, шуның вә-

киле. *Бу музейда немецларның иң соңгы экспрессионистларыннан Крихнер картиналарын, «Кояш чәчәкләре»н --- һәм Нольденың кайбер картиналарын әйтеп китәргә кирәк.* Г.Гали. *Җәмгыятьтәге төрле рәхимсезлекләрнең, сугышларның матурлыкка, кешелеклелеккә дошманлыгын --- ачык итеп күрсәтеп, укучыны сурәтләүләр белән тәэсирләндерү – экспрессионистларның төп максаты.* Әдәбият

**ЭКСПРЕССИОНИСТИК** *с.* Экспрессионизмга хас, экспрессионизмга бәйле, шуңа нигезләнгән. --- *корабның хәвефле һәм киеренке хәрәкәте, ул көткән фаҗига күпсанлы экспрессионистик детальләр, ассоциацияләр ярдәмендә ассызыклана.* Р.Ганиева

**ЭКСПРЕ́ССИЯ** *и. лат.* Хис һәм кичерешләрнең сөйләмдә, биюдә, актёр уенында һ.б.ш.да чагылышының, гәүдәләнешенең көчлелеге, тәэсирлелеге, җанлылыгы. --- *сәхнәгә --- микрофон тоткан Пугачёва килеп чыга һәм, колтә чәченә бутала-бутала, башын артка ташлап, сәхнә буйлап йөреп җырлый башлый. Ул хәрәкәтләр, ул тавыш, ул елмаю, ул экспрессия...* М.Мәһдиев. *Телбизәкләргә, төс һәм жестларга кытлык кичермәгән хәлендә, бу әсәрләрдә чачаклау-чуклау, ясалма экспрессия, ахыр килеп, әдәби алым гына икәнлеге сизелерлек дәрәҗәдәге әвеш-тәвеш китерүләр дә күзгә ташланмый.* М.Вәлиев

**ЭКСПРЕ́ССИЯЛЕ** *с.* Хис һәм кичерешләрне чагылдырган, хисләр чагылышы көчле булган; сәнгатьле, тәэсирле. *Эмоциональ лексика, хисләрне, мөнәсәбәтне белдерүдән тыш, үтемле, тәэсирле булырга, тыңлаучыга, укучыга, әңгәмәдәшкә барып җитәргә, ягъни экспрессияле булырга тиеш.* И.Абдуллин. *Шул үзенчәлеге яңа әдәбиятны заманча, актуаль йөкләмәле, оригиналь экспрессияле һәм эчке мәгънәле итә.* М.Гайнетдинов

**ЭКСПРЕ́ССИЯЛЕЛЕК** *и.* Экспрессияле булу үзлеге. *Экспрессиялелек күзлегеннән караганда, сүзләр берничә катламга бүленәләр ---.* И.Абдуллин. *--- шул ук вакытта сәнгать эмоциялелеккә, экспрессиялелеккә генә кайтып кала алмый, чөнки аның объектив вазифасы киңрәк.* К.Гыйззәтов

**ЭКСПРЕ́СС-ЛАБОРАТО́РИЯ** *и. лат.* Химик анализларны тиз һәм оператив ясау лабораториясе. *Хәзерге вакытта ул Казанның бер хастаханәсендә экспресс-лабораториядә эшли.* Шәһри Казан. *Агрохимия экспресс-лабораториясе*

**ЭКСПРЕ́СС-ПО́ЧТА** *и. лат.-ит.* Корреспонденцияне тиз һәм оператив рәвештә, гадәттә өстәмә түләү исәбенә, илтеп тапшыра торган почта хезмәте. *Р.Хәбибуллинның пластик картасы Мәскәүдәге баш банктан 12 мартта ук экспресс-почта белән килгән ---.* Безнең гәҗит

**ЭКСПРЕ́СС-ЫСУЛ** *и.* Берәр өлкәдә кирәкле нәтиҗәгә бик тиз ирешү мөмкинлеге бирә торган эш ысулы. *Гарифьянов җитәкчелегендә нефть һәм битумда ЭПР тикшеренүләре үткәрелә, һәм алар нефть продуктларында ванадийның күләмен ачыклаучы экспресс-ысул эшләүгә китерә.* Фән һәм тел. *Чит телне өйрәтүдә экспресс-ысул. Зарарлы матдәләрне ачыклау һәм теркәү экспресс-ысулы*

**ЭКСПРОМТ** *и. лат.* **1.** 1) Алдан әзерләнмичә сөйләнгән сүз; кинәт кенә язылган кечкенә шигырь, музыкаль әсәр һ.б. *Миңа тагын-тагын бокаллар суздылар. Тостлар әйттеләр. Хәлил экспромтлар яудырды.* Ф.Яруллин. *Хәзер инде иҗат процессындагы экспромт, импровизацияне әдәби әсәр өстендә җитди һәм дәвамлы эш алыштырды.* Н.Юзиев. *Хәзрәт ялындырмады, кулына каләм-мазар алып тормастан, башында туган экспромтын дөньяга чыгарды ---.* А.Тимергалин

2) Ирекле формада язылган кечерәк музыка әсәре. *Аның яшьлек елларында иҗат иткән төрле сюита, экспромтлары нотага салынмаган, ил буйлап гастрольләрдә йөргәндә таралып, югалып беткәннәр.* Б.Хәмидуллин. *Назлап сыйпаган сыман итеп, бармакларын клавишлар өстеннән йөгертеп узды да экспромтлар уйнарга кереште.* Р.Низами

**2.** *с. мәгъ.* 1) Артык озак уйланып, әзерләнеп тормастан, тиз иҗат ителгән. *Юмор, кызык фикер, экспромт шигырь юлларын адым саен сибеп-чәчеп йөргән, әрәм иткән бу шагыйрьнең рухы гаҗәеп дәрәҗәдә бай.* Р.Миңнуллин

2) Алдан әзерләнмичә, кинәт, шунда ук, бернинди әзерлексез эшләнгән

**ЭКСПРОПРИА́ТОР** *и. лат.* Экспроприацияләүче, экспроприация ясаучы. *Экспроприатор – гади кеше теләндә талаучы икән.* З.Зәйнуллин

**ЭКСПРОПРИА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Дәүләт органнары тарафыннан аерым граждannарның, юридик затларның милкен рәсми рәвештә көч белән бушлай яки сатып алу. *Аның Уралда ике экспроприациягә катнашкан Әхмәт Хәйруллин исемендә йөргән кеше икәнен монда ачтылар.* Г.Ибраһимов. *Җитмешенче елларда совет матбугаты һәм телевидениесе --- теге яки бу партия өчен акча вә алтын-көмеш кебек кыйммәтле әйберләрне талап я урлап алуны экспроприация дип атап --- килде.* Р.Мирхәйдәров

2) Бер сыйныфның икенче бер сыйныфны элекке социаль хәленнән һәм шәхси милектән мәхрүм итүе. *Кулакларга тулы экспроприация ясалды.* Советлар Союзы Коммунистлар партиясе тарихы

**ЭКСПРОПРИА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Экспроприация ясау. *Күзгә карап халыкны экспроприацияләү (большевиклар жаргоны, безнеңчә – талау) дәвам итә.* Р.Зәйдулла. --- *алпавытларны экспроприацияләү исәбенә эшче һәм крестьяннарның тормыш шартларын яхшырту өчен --- бөтенесе эшләнде.* Татарстан тарихы

**ЭКССУДАТ** *и. лат. мед.* Ялкынсыну вакытында, кан тамырларыннан саркып, тукымаларга, тән куышлыкларына җыелган сыекча

**ЭКССУДАТИВ** *с. мед.* Сыекчалы, экссудаты булган. *Яфрак төнәтмәсе хроник экзема, дерматомикоз, экссудатив диатез (ягъни тире авыруларыннан) --- кулланыла.* Файдалы киңәшләр. *Ул [Каминский], су ярдәмендә пневмонияне, рахит, экссудатив диатез һәм геморрой, неврозлар, вена чирләрен --- һ.б. хасталарны дәваларга мөмкин, ди.* Юлдаш

**ЭКССУДАТИВЛЫ** *с. ялг. к.* **экссудатив**. *Ләкин апрель-май аенда яңадан өзлектем – туберкулёзлы үпкәмдә экссудативлы плеврит хасил булды.* Г.Ибраһимов

**ЭКССУДАТЛЫ** *с. мед. к.* **экссудатив**

**ЭКССУДА́ЦИЯ** *и. мед. лат.* Экссудат барлыкка килү процессы

**ЭКСТАЗ** *и. гр.* Шашыну дәрәҗәсенә җиткән чиктән тыш шатлану, соклану халәте, чиктән тыш рух күтәренкелеге. *[Хәбирнең] урамнардан керәсе килмәде. Әллә нинди бер экстазга бирелеп, ул бик озак каңгырап йөрде.* Ш.Хөсәенов. *– Аңламыйм! Аңлый алмыйм! Беркайчан да аңлый алмаячакмын! – дип шатланып такмаклый-такмаклый күкрәк кагучы томаналыкның нииндидер мистик экстазы бу.* Кызыклы психология

**Э́КСТАЗИ** *и. гр.* Көчле тәэсирле, җитештерү, тарату тыелган ярымсинтетик наркотик. *Бөекбритания наркологлары белдерүенчә, тәмәке тарту һәм аракы эчү сәламәтлеккә марихуана,*

*--- экстазидан да күбрәк зыян китерә.* Мәдәни җомга

**ЭКСТЕНСИВ** *с.* 1) Сыйфатны яхшыртмыйча, бары тик күләмне арттыру, үстерү белән бәйле, шундый принципка нигезләнгән. *Шулай итеп, 50 нче еллар уртасында – 60 нчы еллар башында икътисад экстенсив юл белән үсә.* Татарстан тарихы. *XVIII гасырның икенче яртысында авыл хуҗалыгы, гадәттәгечә, экстенсив, ягъни сөрүле җирләрне киңәйтү, терлекләрнең баш санын арттыру юлы белән үсә.* Россия тарихы

2) *махс.* Техник прогресска игътибар итми генә, бары тик өстәмә материаллар һәм кеше ресурслары исәбенә үсә торган. *Чәчү мәйданнарын яки көтүлекләрне арттыру исәбенә үсә торган экстенсив хуҗалыклардан аермалы буларак, интенсив хуҗалыклар камилләшкән машиналар исәбенә үсәләр.* Политэкономия. *Беренче тәкъдим: Россия кебек бүгенге иң бай илдә иң ярлы халык яшәү практикасын бетерү һәм шунлыктан, экстенсив методлардан, алымнардан баш тартып, интенсивлыкка күчү.* Казан утлары

**ЭКСТЕНСИВЛЫК** *и.* Экстенсив булу. *Яңа гына яулап алынган җирләргә руслар белән бергә мәҗбүри рәвештә татарлар да җибәрелә торган булган. Димәк, татарлар да, телиме-юкмы, экстенсивлык алымнары белән эш итеп яшәү рәвешенә җәлеп ителгәннәр.* Ш.Җәләлиев. *Хуҗалыкның эш итү алымының экстенсивлыгы*

**ЭКСТЕРН** *и. лат.* 1) Аерым уку йортында укымыйча, мөстәкыйль өйрәнеп, тиешле имтиханнарны тапшыручы кеше. *Риза булсалар, ун класс өчен иртәгә үк экстерн тәртибендә имтиханнар тапшырам.* М.Хуҗин. *Фатихның хыялы – экстерн юлы белән өлгергәнлек аттестаты алып, Казан университетына керү.* М.Мәһдиев

2) 1917 елга кадәрге Россиядә, ябык уку йорты каршындагы интернатта яшәмичә, өйдән килеп йөреп укучы. *1917 елгы февраль революциясеннән соң, Кәшифә частный гимназиянең экстерн бүлегенә кереп, аны да уңышлы тәмамлый.* Ф.Мөслимова

3) *иск.* Иске Россиядә, тәҗрибә алу максаты белән, берәр хастаханәдә яки учреждениедә штаттан тыш эшләүче табиб

**ЭКСТЕРНАТ** *и. лат.* 1) Уку йортында укымыйча, читтән килеп, шунда укытылган фәннәрнең тулы курсы өчен имтиханнар тапшыру тәртибе. *Заманча мәгарифнең тагын бер яңалыгы – баксаң, вузларда белгечләрне «тиз-тиз генә» әвәләп чыгара торган бүлекләр – экстернатлар ачу модага кереп киткән икән.* Татарстан яшьләре

2) *иск.* Тәҗрибә туплау өчен, берәр хастаханәдә яки учреждениедә штатта тормыйча эшләүче табиб вазифасы, экстерн вазифасы

**ЭКСТЕРРИТОРИАЛЬ** *с.* Экстерриториальлек хокукына ия булган. *--- Кытай законнары үз көчләрен югалталар, ягъни бу кварталлар экстерриториаль дип йөртелгән режимнан файдаланалар.* Яңа тарих

**ЭКСТЕРРИТОРИАЛЬЛЕК** *и.* Дәүләтләрнең үзара чит ил вәкилләренә яки дипломатик агентларга биргән махсус хокуклары һәм өстенлекләре (торак һәм шәхес иминлеге, урындагы кануннарга буйсынмау, йөкләмәләрдән һәм салымнардан азат булу, үз илләрендә кабул ителгән кануннар нигезендә яшәү мөмкинлеге)

**ЭКСТЕРЬЕР** *и. лат.* 1) *а.х.* Терлекнең тышкы төзелеше, гәүдә торышы. *Солтан исә, тешләрен карап, яшьләрен билгеләде, тоякларын тикшерде, рәссамнарга бер якын килеп, бер ерак китеп, атларның экстерьерын бәяләргә тотынды.* А.Расих. *В.В. Алпатов --- бал кортларының экстерьер билгеләрен бәяләү методикасын төзегән, борынчык озынлыгының географик үзгәрүчәнлеген өйрәнгән.* Татар балы

2) *арх.* Бинаның тышкы күренеше. *Казанның Химиклар мәдәният сарае экстерьерында (парк фасады) алмагач утыртучы кыз һәм кызның иңнәренә кулын куйган көчле ир фигуралары нәкъ менә шушындый характерда башкарылган.* Татарстан яшьләре

**Э́КСТРА** *с. лат.* 1) Иң яхшы, югары (товарның сорты тур.). *Мирзахан дигәне портфеленнән бер шешә чыгарып өстәлгә утыртты: – Борчылмагыз, әфәндем, үзебез белән кыстыра килдек. Экстра!* Р.Батулла

2) *күч.* Затлы, асыл, менә дигән. *Ә Мәрьям сөенеп бетә алмас. Дания белән чагыштырганда, ул – беренче сорт, экстра!* Н.Фәттах

**Э́КСТРА-** Кушма сүзләрнең «нәрсәдәндер тыш, аңа карамаган» яки «бик әйбәт, югары сыйфатлы» мәгънәсен белдергән беренче компоненты: *экстралингвистик, экстраординар*

**ЭКСТРАВАГАНТ** *с. лат. кит.* Гадәти булмаган, гомуми кабул ителгән нормалар, гореф-гадәт, мода кысаларына сыймый торган, үзенчәлекле. *Колакларында бриллиант алкалар, башларындагы чәчләре ул заманда «хала» дип йөртелгән, яхшылап өелгән биек причёскалы, әле яңа гына модага кереп бара торган гаҗәеп кыйммәтле әкәмәт экстравагант итек-оеклар...* Р.Мирхәйдәров. *Төрле сирәк очрый торган экстравагант диеталарга бик сак карарга киңәш ителә.* Сәламәтлек нигезләре

**ЭКСТРАВАГАНТЛЫК** *и. кит.* Киемдә, үзен тотышында гадәти булмаган, үзенчәлекле, сәер нәрсәләр белән мавыгучанлык, экстравагант булу. *Экстравагантлыктан курыкмасагыз, кызыл-сары галстук, комач төсендәге ботинкалар, ялтыравыклы күлмәк киңәш итәр идек.* Сөембикә

**ЭКСТРАДИ́ЦИЯ** *и. лат.* Экстрадицияләү эше. *Кайбер күзәтүчеләр фикеренчә, Закаев эше халыкара каршылыклар да китереп чыгарырга мөмкин, чөнки экстрадиция, ягъни кулга алынган кешене чит илгә тапшыру – юридик кына түгел, сәяси мәсьәлә дә.* Татарстан яшьләре

**ЭКСТРАДИ́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Чит дәүләт кануннары нигезендә җинаять эшләгән кешене җавапка тарту яки, суд карарын тормышка ашыру максаты белән, шул илгә кайтару. *Русия властьлары, ил гражданнарын экстрадицияләү Конституциягә каршы килә, Луговой гаепле табылса, эшне Русия суды караячак, дип бара.* Татарстан яшьләре. *--- моңарчы качып йөргән лидерларның берсе Зөфәр Үтәгәновны Черногориядә тотып, Русиягә экстрадицияләделәр.* Безнең гәҗит

**Э́КСТРА-КЛАСС** *и. лат.* **1.** 1) Югары квалификацияле, үз эшенең остасы

2) Югары сыйфатлы әйбер. *Карьера турында уйлап башы каткан хатынкыз иң элек үз абруе турында уйлый: аның бөтен нәрсәсе «экстра-класс» булсын, хәтта баласы да ---.* Сөембикә

**2**. *с. мәгъ.* 1) *к.* **экстраклассслы** (*1 мәгъ*). *Безнең татар әдәбиятында публицистиканы беркайчан да санга сукмадылар, шуңа күрә экстра-класс публицистлар да юк.* М.Галиев. *Экстра-класс хирург. Экстра-класс биюче*

2) *к.* **экстраклассслы** (*2 мәгъ*). *Экстра-класс компьютер. Экстра-класс җиһаз*

**Э́КСТРАКЛАССЛЫ** *с.* 1) Үз белгечлегендә иң оста, югары дәрәҗәдәге профессионал булуы белән аерылып

торган. *Шуңа да экстракласслы атлетлар елына күп дигәндә ике-өч марафонда гына катнаша.* Шәһри Казан

2) Югары сыйфатлы, бөтен яктан килгән. *«Ил-62» Сингапурның Чанги аэропортына төшеп кунаклый, --- һәм без экстраклассны аэровокзал бинасыннан Сингапур җиренә аяк басабыз.* Ә.Рәшит

**ЭКСТРАКОРПОРА́ЛЬ** *с. мед.* Җенес күзәнәкләрен хатын-кызның җенси органнарыннан тыш шартларда аталандыруга бәйле. *Татарстанда әлеге көндә ЭКО, ягъни экстракорпораль аталандыру ярдәмендә бала табарга теләүче 6 мең пар чиратта тора.* Мәйдан. *Бик күп парлар «баланы пробиркадан алу»ны, ягъни экстракорпораль аталандыру ысулын ышанычлырак дип саныйлар.* Юлдаш

**ЭКСТРАКТ** *и. лат.* 1) Дару препараты буларак үсемлек (сирәк кенә терлек) тукымаларыннан алынган матдә, экстрактлау нәтиҗәсендә барлыкка килгән сыгынты, сөземтә. *Утчәчәк экстракты адонизид, кардиовален, Бехтерев микстурасы составларына керә.* Сәламәтлек нигезләре. *Кан тамырлары варикоз киңәйгәндә, көненә ике тапкыр мондый катнашма сөртү файдалы: 1 аш кашыгы ромашка сыгынтысына (экстракт) 1 чәй кашыгы алтын мыек (каллизия) төнәтмәсен кушалар.* Мәдәни җомга

2) Җиләк-җимешләрнең куертылган согы. *Җиләк экстракты*

3) *күч.* Берәр документ, әсәр һ.б.ш.ның кыскача эчтәлеге

**ЭКСТРАКТЛАНУ** *ф. кайт. юн. к.* **экстрактлау**. *Кайчакта зарарлы яки биологик актив матдәләрнең тәэсирен акрынайтучы катнашмалар экстрактланмый.* Урман аптекасы

**ЭКСТРА́КТЛАУ** *ф.* Махсус эреткеч матдәләр ярдәмендә сыек яки каты хәлдәге икенче бер әйбернең кайбер состав өлешләрен аерып алу; шул матдәнең экстрактын ясау

**Экстрактлап бетерү** Тулысынча экстрактлау

**Экстрактлап тору** Озак вакыт дәвамында даими экстрактлау

**ЭКСТРА́КТОР** *и. лат.* 1) Экстракция (*2 мәгъ.*) аппараты

2) *мед.* Теш суыру, тәндәге чит җисемне (мәс., пуля) алып ташлау әсбабы

3) *тех.* Атылган гильзаны патрон оясыннан чыгару җайланмасы. *Мылтык экстракторы*

**ЭКСТРАКЦИОН** *с.* 1) Экстракциягә караган, экстракциягә мөнәсәбәтле // Экстракция өчен билгеләнгән. *Экстракцион приборлар*

2) Экстракция (*2 мәгъ.*) юлы белән алынган

**ЭКСТРА́КЦИЯ** *и. лат.* 1) *махс.* Суыру, суырып ташлау, суырып чыгару, алу, алып ташлау эше (мәс., тешне)

2) *хим.* Су, спирт, бензол һ.б.ш. эреткечләр ярдәмендә билгеле бер катнашмадан берәр матдәне эретеп, аерып чыгару процессы

**ЭКСТРА́КЦИЯЛӘҮ** *ф.* Экстракция ясау

**Экстракцияләп бетерү** Тулысынча экстракцияләү

**Экстракцияләп тору** Озак вакыт дәвамында экстракцияләү

**ЭКСТРАЛИНГВИ́СТИК** *с.* Экстралингвистикага бәйле. *Кальканың калька икәнлеген белү өчен, экстралингвистик детальләрне белү мәҗбүри.* Р.Әхмәтьянов. *Орфоэпиябез күп төрле лингвистик һәм экстралингвистик йогынтылар кичерә.* Р.Абдуллина. *Заманында рус лингвистикасы кайбер экстралингвистик проблемалар белән шөгыльләнүдән читләшә башлаган иде.* И.Низамов

**ЭКСТРАЛИНГВИ́СТИКА** *и. лат.* Тел үсешенең этнолингвистик, тарихи, географик һ.б. тышкы факторлар җыелмасын өйрәнә торган фән

**ЭКСТРАОРДИНАР** *с. кит.* 1) Гадәттән тыш, искиткеч, сирәк очрый торган. *9 июньдә гимназия советының «экстраординар» киңәшмәсе барган конференцзалга берничә дистә гимназист килеп керде.* Җ.Тәрҗеманов. *Ләкин камыр малайның «ахмаклыгы» әлеге экстраординар вакыйга белән генә тәмамланмый.* Х.Ибраһим. *Экстраординар шәхес*

2) *иск.* Штаттан тыш, кафедрасы булмаган (гыйльми вазифа тур.). *Яковкин инде аңа университетта хокук буенча экстраординар профессор булырга тәкъдим ясаган.* Җ.Тәрҗеманов

**ЭКСТРАПОЛЯ́ТОР** *и. лат.* Автомат идарәле системаларда идарә ителә торган объектның эшләвен тасвирлый торган дифференциаль тигезләмәләрне чишү өчен хезмәт иткән цифрлы хисаплау җайланмасы

**ЭКСТРАПОЛЯ́ЦИЯ** *и. лат.* 1) *кит.* Билгеле күренешнең бер ягын күзәтү нәтиҗәләрен күренешнең башка өлешенә карата да кабул итү, күчерү

2) *мат.* Берәр функциянең билгеле кыйммәтләреннән файдаланып, шушы функциядән тыш булган кыйммәтләрне табу. *Бу саннарга таянып һәм экстраполяция ысулын кулланып, бүгенгесе көндә якынча 600 – 650 мең керәшен яши, дип фараз кылырга була.* Туганайлар

**ЭКСТРА-ПО́ЧТА** *и. лат.* Ашыгыч рәвештә, чираттан тыш җибәрелә торган почта

**ЭКСТРАСЕНС** *и. лат.* Парапсихологиядә сизеп белү, биокырлар кабул итү һәм аларга тәэсир итү сәләтенә ия кеше. *– Этегез чирләгән икән, – дип каршылады аны экстрасенс.* Ф.Яруллин. *Элекке җәмгыятьтә дә экстрасенс, гипнозчы, күрәзәчеләрнең зур күпчелеге нәкъ менә хатын-кызлар иде бит.* Р.Фәизов

**ЭКСТРАСЕНСОР** *с.* Парапсихологиядә сизү органнары катнашыннан тыш сизеп белү формаларына бәйләнешле. *Колхоз базарыннан ерак түгел бер ишегалдында ике бүлмәле янкорманы арендага алып, Фаил абый экстрасенсорик дәвалау эшенә ныклап керешкән иде.* К.Кәримов. *Соңгы вакытлардагы экстрасенсор шау-шуны, барлык кешеләрнең дә оккульт фәннәр белән кызыксынуын Сез нидән күрәсез?* Юлдаш

**ЭКСТРАСЕНСО́РИКА** *и. лат.* Парапсихологиядә: кешенең экстрасенсор сәләтләре белән бәйле күренешләр җыелмасы. *Бу бигрәк тә йогизм, телепатия, экстрасенсорика, спиритизм кебек өйрәтмәләрнең кайбер тайпылышларына кагыла.* И.Әмирханов. *Галимнәр фаразлавынча, якын киләчәктә туган сабыйларның 90 процентының аурасында әлеге төс шәйләнәчәк, димәк, алар гайре табигый сәләтләргә (телепатия, экстрасенсорика, фәнни иҗат) ия булачак.* Мәдәни җомга

**ЭКСТРАСЕ́НЦИЯ** *и. лат. к.* **экстрасенсорика**. *Экстрасенция төшенчәсе*

**ЭКСТРЕМАЛ** *и. рус* 1) Экстремаль спорт төрләрен яратучы һәм шулар белән шөгыльләнүче кеше. *Британиядә экстремаллар күккә 300 метр биеклеккә күтәрелеп никахлашкан.* Мәдәни җомга

2) *күч.* Еш кына үзен куркыныч астына куючы, шуннан тәм табучы кеше. *Әмма «беркем дә булдыра алмаганны башкарып уңышка ирешәм, шаккатырам, мин – герой, мин – экстремал, игътибар җәлеп итәм» кебек ахмак шапырынуларны үз эченә алган селфи табигатьнең кодрәтле көче – инстинктны да басарга сәләтле ләбаса.* Татарстан яшьләре

**ЭКСТРЕМАЛЬ** *с.* 1) Температура, басым һ.б. физик күрсәткечләре гадәттәгедән аерылып торган. *Экстремаль басым*

2) Гадәти булмаган, күнегелмәгән һәм чиктән тыш авыр. *Сизәбез: болар гади сораулар түгел, аларга җавап бирү өчен, язучыдан экстремаль шартлардагы экстремаль сурәтләү чаралары таләп ителә.* Ә.Дусайлы. *Ашыгыч чакыруларга йөрмәгән врач түгел түгелен. --- төрлесе булды, әмма мондый хәлгә тарыганы юк иде. Медиклар телендә моны экстремаль очрак диләр.* Д.Гайнетдинова

**ЭКСТРЕМИЗМ** *и. лат.* Чиктән тыш карашларга һәм хәрәкәтләргә нигезләнгән эшчәнлек; җәмгыятьнең бер өлешенә карата көч куллану карашлары, көч куллануны аклаган пропаганда һәм сәясәт. *Шунысы гыйбрәтле: нинди булуына һәм ни рәвешле чагылуына карамастан, экстремизм Татарстанның сәясәт мәйданыннан тулысынча диярлек кысып чыгарылды ---.* Мирас

**ЭКСТРЕМИСТ** *и. лат.* Чиктән тыш карашлар яклы кеше; экстремизм тарафдары. *Дагстанда даими сугыш хәрәкәтләре инде тынды, экстремистлар чигенде.* Сөембикә

**ЭКСТРЕМИ́СТИК** *с.* Экстремизмга бәйле, экстремистларга хас. *Бүгенге көндә Татарстанда экстремистик юнәлештәге формаль булмаган ике яшьләр хәрәкәте исәпләнә.* Мәдәни җомга. *Оренбург өлкәсендә дини китапларны экстремистик әдәбият дип тану зур иҗтимагый резонанас тудырды.* Ирек мәйданы

**ЭКСТРЕМИСТЛЫК** *и. к.* **экстремизм**. *Әмма бездә экстремистлык чалымнары күренгәли.* М.Галиев. *Шулай ук, мәчет төзелеше, динара һәм милләтара татулыкны юкка чыгарып, дини экстремистлык үсешенә китерәчәк, дип борчылалар шовинист хисле милләтчеләр.* Шәһри Казан

**ЭКСТРЕ́МУМ** *и. лат. мат.* Функциянең иң зур һәм иң кечкенә кыйммәте (максимум һәм минимум төшенчәләрен берләштерә). *$Log = a^x$ функциясенең экстремумын табабыз.* Математика

**ЭКСЦЕ́НТРИК** I *и. фр.* 1) Эксцентрика жанрында эшләүче артист. *Цирк артисты, эксцентрик Яков Никифоров, акробат Саша Маленький, иллюзионист Андрей Фёдоров, җырчылардан Искалиев, Дудин һәм башка бик күпләр бар иде.* Г.Әпсәләмов

2) *психол.* Кыланышы үтә сәер булган, клиник нормаларга сыймаган кеше

**ЭКСЦЕ́НТРИК** II *и. тех. фр.* Машина яки механизмның геометрик үзәктән читтә урнашкан күчәр тирәсендә әйләнә торган дискы

**ЭКСЦЕ́НТРИК** III *с.* 1) Эксцентрика жанрына караган, эксцентрика рәвешендәге, көлкеле алымнарга нигезләнгән. *Артист Олег Хан, таяктрость тотып, европача киенеп, шикле хәрәкәтләр ясап, эксцентрик кыланышлар белән ишанны уйный ---.* Р.Батулла. *Әлеге әсәр туган илен ташлап китүчеләрдән үтергеч рәвештә көлүче сатирик комедия итеп куела. Кәмит уенына хас эксцентрик, «зәһәр» буяулар кулланыла.* Казан утлары

2) *күч.* Гаҗәп, гадәттән тыш сәер, оригиналь, мәзәкчән; юләрсыман. *Эксцентрик бала*

**ЭКСЦЕ́НТРИКА** *и. лат.* 1) Театр, цирк, кино, эстрада кебекләрдә чынбарлыкны артык комиклаштыру, сәер персонажлар, тузга язмаган күренешләр, көлкеле көтелмәгән кыланышлар аркылы чагылдыру ысулы, шуларга нигезләнгән жанр. *Совет театры тарихыннан без И.Ильинский, В.Марецкая, С.Бирман, М.Бабанова кебек эксцентрика һәм гротеск мәктәбен үткән шактый күп мәшһүр актёрларны беләбез.* И.Илялова

2) Берәр нәрсәнең гадәти булмаган, кычкырып торган, күзгә ташланган рәвеше, күренеше. *Модалы стиль: эксцентрика, элегант минимализм, спорт стилендәге кэжуал.* Асылъяр

**ЭКСЦЕ́НТРИКЛЫК** *и.* Эксцентрик булу, гаҗәеплек, сәерлек, мәзәкчәнлек

**ЭКСЦЕСС** *и. лат. кит.* 1) Берәр нәрсәнең артык, чамасыз (гадәттә тискәре рәвештә) беленүе, чагылуы, чиктән ашуы. *Хисләр эксцессы*

2) Берәр тискәре, урынсыз, процессхәлләрнең гадәти барышын боза торган хәл, вакыйга, күренеш. *Татарстан үз территориясендә берниндидә эксцессларга, экстремизмга юл куймый.* Фәнни Татарстан

**ЭКС-ЧЕМПИОН** *и. лат.-ингл.* Элекке чемпион. *Икенче уенда исә ул дөньяның экс-чемпионын пыр туздырып ташлады.* Р.Миңнуллин. *– Рәшит Нәҗметдиновны шахматка искиткеч иҗади мөнәсәбәте башкалардан аерып торды, – дип хөрмәтләп исенә төшерде дөньяның экс-чемпионы Михаил Таль.* М.Хуҗин

**Э́КТО-** *гр.* Кушма сүзләрдә «тышкы» мәгънәсен белдерә торган беренче кисәк

**ЭКТОГЕНЕЗ** *и. гр.* Эволюцион тәгълиматта: эволюция тирәлекнең турыдан-туры тәэсире астында бара, дип раслый торган бер агым. *Ламаркның эволюция теориясе күп яктан эктогенезга нигезләнгән*

**ЭКТОПАРАЗИТ** *и. гр.* Хайваннар тәнендә һәм үсемлекләрдә яшәүче организмнар, тышкы паразитлар. *Ветеринария аптекаларында, зоокибетләрдә эктопаразитлардан саклану чаралары хәзер күпләп сатыла ---.* Бөгелмә авазы

**ЭКУМЕНИЗМ** *и. гр.* Христиан диненең төрле агымнарын, тармакларын берләштерү максаты белән XX гасыр башында барлыкка килгән хәрәкәт. *Россиядә --- экуменизмны да дәүләт дине дип игълан итәргә тырышу барып чыкмый.* Россия тарихы

**ЭКУМЕНИСТ** *и. лат.* Экуменизм тарафдары. *Экуменистлар җәмгыяте*

**ЭКЮ** I *и. фр.* Урта гасырларда Франциядә алтын яки көмеш тәңкә

**ЭКЮ** II *и. ингл.* Европа берлеге һәм Европа экономик берлегенә караган илләрдә 1979 – 1998 елларда файдаланылган валюта берәмлеге. *1991 елдан алып 1994 еллар арасында гына да «ТАСИС» үзенең партнёрларына кире кайтарусыз 1870 миллион экю бирде.* Ватаным Татарстан

**ЭЛАСТИК** *и. гр.* **1.** Сыгылмалы полимерларның гомуми атамасы

**2.** *с. мәгъ.* 1) Сыгылмалы, сузылучан; сузылып, тиз генә кире үз хәленә кайтучан. *Шуларның янә берсе – эластик җисемнәрнең аркылы бәрелеш теориясе.* Т.Әйди. *--- пирамидаль кимерчәкләргә ике яклап эластик мускул җепселләре беркетелгән.* Ф.Сафиуллина. *Йөрәкнең стеналары тыгыз һәм эластик булганлыктан, артерияләр бу басымга чыдыйлар һәм тартылып киңәяләр.* Анатомия

2) Каучук бирә торган. *Көньяк Азиядәге эластик фикусның --- сөтчел сыекчасы югары сыйфатлы каучук бирә.* Л.Мәүлүтова

3) Сыгылмалы полимердан эшләнгән

4) *күч. иск.* Салмак, талгын, йомшак. *Эластик хәрәкәтләр*

**ЭЛА́СТИКЛЫК** *и.* Эластик булу сыйфаты, сыгылмалылык, сузылучанлык. *Суынганнан соң корычның пластиклыгы бик нык кими, ә эластиклыгы арта.* Физика. *Шуңа күрә дә Рәсәй нормаларында тимербетон элементларның чыдамлыгын хисаплау һаман да эластиклык теориясенә нигезләнгән ысуллар белән башкарыла.* Фән һәм тел. *Эластиклык көче. Эластиклык коэффиценты*

**ЭЛАСТИН** *и. гр. биол.* Склеропротеиннар төркеменнән кан тамырлары

стеналары, тире һ.б.ш.ның җепселләр составына керә, аларның сузылмалылыгын тәэмин итә торган аксымнарның берсе. *Мезотерапия ысулы белән тән тиресенә кирәк кадәр генә витаминнар, дарулар, эластин, коллаген матдәләре, макро һәм микро элементлар, микропептидлар кертелә.* Сөембикә. *Шоколад составында булган какао мае тән күзәнәкләрендә коллаген, эластин барлыкка китерә торган витаминнар бүлеп чыгара ---.* Шәһри Казан

**ЭЛӘГЕШҮ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **элэгү** (*1 мәгъ.*)

2) *сөйл. күч.* Сөйләшкән җирдән кинәт кенә ызгышып, тиргәшеп китү, сүзгә килү. *Бигрәк тә кырыс табигатьле Иван Нилович белән еш эләгешкәлиләр иде алар.* М.Хәсәнов. *Шуның өстенә әтием бик басынкы, бик ипле холыклы. Кеше белән эләгешеп, үч саклап та йөрми.* Э.Шәрифуллина

3) *күч.* Сугышып китү. *Шуннан киттек эләгешеп: изүгә-изү ябыштык.* Т.Миңнуллин. *--- бәйрәм көннәрендә кызмача булып кичке уенга чыккан егетләр юктан гына эләгешеп бәргәләшеп алалар иде, әмма шул коры кул белән бергәләүдән ары узмыйлар иде.* М.Мәһдиев

**Эләгешеп алу** Кыска вакыт эчендә, аз гына, җиңелчә генә эләгешү. *Китте чыгышлар, бәхәс. Директор белән завуч эләгешеп алды.* М.Мәһдиев. *Нинди дуслар Милашкин белән Гыйльманов бүген нәрсәгәдер эләгешеп алдылар.* Х.Камалов

**Эләгешеп китү** Кинәт кенә эләгешү. *Еракта улларының нидер турында кызып-кызып бәхәсләшүе колагына чалынды. «Барыйм әле, эләгешеп китмәсеннәр тагы!» – диде ул үз-үзенә.* Ф.Яруллин. *Өлкән абзыйлар, эләгешеп китеп, берәвенең җилкәсенә, бөкресен кашып, себерке сабы кундырган икән!* А.Гыйләҗев

**Эләгешеп кую** *к.* **эләгешеп алу**

**Эләгешеп тору** Еш кына, даими, әледән-әле эләгешү. *Җитмәсә, теге аждаһа карчык белән күчәрләр гел эләгешеп тора.* А.Гыйләҗев

**ЭЛӘГҮ** *ф.* 1) Нинди дә булса берәр нәрсәгә орынып, ышкылып, тиеп, хәрәкәт иткәндә тоткарланып, терәлеп яки туктап калу. *Кинәт аның чаңгысы кар астыннан тырпаеп торган ботакка эләкте дә, чаңгы бавы шарт итеп өзелде.* Г.Әпсәләмов. *Ертыла башлаган күлмәк тагын каядыр эләкте.* Ф.Яруллин

2) Махсус төбәлгән, тиешле, кирәк урынга туры килү, тию. *Инде исән-сау гына авылга керәбез дигәндә, фашист орудиесенең бер снаряды эләгеп, танкның башнясын алып ыргытты.* Н.Әхмәдиев

3) Очраклы рәвештә тиеп китү, бәрелеп китү. *Икенчеләре исә: «Әй-йе, ниһаять, Борһанның да чамасыз селтәнүчән чалгысы чакма ташына эләкте, ахрысы», – дип, Мәдинәне якладылар.* М.Хәсәнов. *Кичә экскаватор чүмече бер торбага эләкте.* З.Дәүләтов

4) Кабу, тотылу. *Бер-ике мәртәбә ятьмә салдылар. Балык шактый эләкте.* А.Мифтахетдинов. *Ташбаш, жумба, әле бәп-бәләкәй сыла, тыгыз алабуга балыклары да хәйран гына эләкте.* Ә.Гаффар

5) Һич уйламаганда яки очраклы рәвештә табылу, кул астына туры килү. *Кулына ниндидер чыбык килеп эләкте.* А.Гыйләҗев. *Рәшидә ирексездән йодрыкларын йомарлады, кулына әллә кайдан балта килеп эләкте.* Р.Камалов. *Эзләгәндә яңа күлмәкне, Кулларыма авыр чулпы сыман Көмеш медаль килеп эләкте.* Д.Сирай

6) Кая да булса барып чыгу, килеп чыгу. *Гомерендә олы су күрмәгән Хикмәт, берничә иптәше белән көймәдә океан киңлегенә кереп китеп, штормда чак исән калып, ниһаять, Багам утрауларының берсенә килеп эләкте.* М.Галиев

7) *сөйл.* Тап булу, туры килү, очрау. *Миңа алар тагын койма яңгырга эләкте.* С.Поварисов. *Өч-дүрт адым атлавы булды, чокырлы җир эләкте бугай – бата башлады.* Л.Закирова

8) Кулга алыну, тоткынлыкка тарыгу. *Ул фронтка китте, чолганышта калды, әсирлеккә эләкте ---.* Г.Әпсәләмов. *Тик ул качып өлгермәде, немец кулына эләкте.* А.Расих. *Азинның аты, чокырга туры килеп, сөрлегеп китте, начдив җиргә очып төште һәм дошман кулына эләкте.* Р.Йосыпов

9) Җинаять дип бәяләнә торган эш эшләп, кулга алыну. *Аз гына нәрсә белән тотылып эләктең исә, --- изеп бетергәнче кыйныйлар.* Г.Камал. *«Исән булса, барыбер эләгәчәк!» – диләр 63 млн сум урлап качкан инкассатор турында.* Ватаным Татарстан

10) Берәүнең кулына төшү, карамагына, игътибарына юлыгу. *Шөкер, хат Гайфулла кулына эләкмәде.* Ф.Яруллин. *Миңа «Шәфәкъ вакыты» дигән шигырьләр җыентыгы эләкте.* Т.Нәҗмиев

11) Килешмәгән, ярамаган гамәлдә тотылу, фаш ителү. *Миңа сиңа кирәк булса, гомеремдә бер ялганлаган идем, анда да эләктем.* Р.Ишморат

12) Теләмәгән берәрсенә яки берәр нәрсәгә юлыгу, тап булу. *Бөтен авылда «Мин кем!» дип йөргән Гөлчирә әнә шул шуклык аркасында гына үзеннән шактый олы кешегә – мәктәп директоры Сабир Ишмуратовичка эләкте.* М.Мәһдиев

13) Ихтыярсыздан, көтмәгәндә нинди дә булса шартларга, хәлләргә юлыгу, тарыгу. *Ә бәлки, ул [Флүн], берәр бәхетсезлеккә дучар булып, больницага эләккәндер!* М.Маликова. *Равил юл һәлакәтенә эләкте.* Н.Гыйматдинова

14) Аңлы рәвештә нинди дә булса шартларга ирешү. *Тырыша торгач, бала махсус физика сыйныфына эләкте*

15) Кемгә дә булса тагылу, артыннан иярү. *Кунакка кайткан абыйсына эләгеп шәһәргә китү*

16) Берәр йогынтыга дучар булу, бирелү, ияrү. *Әлфинур, Чулпанияне үзе кебек ирдән уңмаган әйбәт хатынга санап, --- аның йогынтысына эләгеп китте.* З.Фәйзи

17) Берәр эш-хәлгә, вакыйгага туры килү. *Шәһәргә килеп төшүгә бәйрәмгә эләгү*

18) Берәр җиргә җитешә, өлгерә алу, урнаша алу. *Сибгать аганың безнең автобуска эләгүенә мин шатландым.* М.Мәһдиев. *Йөк белән бергә француз пароходының трюмына эләгеп, материкка кайтып егылгач, өмете чынга ашыргa инде ерак калмаган иде.* М.Галиев

19) Берәр эшкә, укуга һ.б.ш. урнашу, билгеләнү. *Хәзер Мәгъшия апаның танышлары гына түгел, республиканың бөтен түрәләре синең кулда. --- шәп эшкә эләктең!* К.Тимбикова

20) Шелтә, җәза бирелү; кыйналу яки тәнкыйтьләнү. *Һәркемнең күңеленә бер генә уй: эләксә нык эләгә инде моңа [Исәнтәйгә], дигән уй килде.* Н.Фәттах. *Ул бала өйдә дә шундый: суксаң да еламый, яхшы гына эләккәне дә бар үзенә.* З.Зәйнуллин

21) *күч.* Берәүдән икенче кешегә күчү, йогу, тию. *Кәбиров башын аска иеп, уйланып торгандай итте, борынын тартып куйды: – Миңа теге чир эләкте бугай.* Ф.Садриев. *Кем очрады шуның берлә йөрүеннән корсаклы булып, янә бер авыру эләкте ---.* М.Сәхапов

22) *күч.* Билгеләнгән урынга, кешегә барып ирешү. *Капитан Божедомов фикердән фикергә оста күчә, шуңадырмы, һәр сүзе адресатына эләгә.* С.Шәрипов

23) *күч.* Нәрсәдән дә булса өлеш чыгу, өлеш тию, насыйп булу. *Малайларга бер кап печенье, ике шоколад һәм ике шешә баллы су эләкте.* А.Гыйләҗев. *Булмаса булмый инде: барыбер йокы эләкмәде.* М.Мәһдиев. *Айрат Бәдретдиновичка тамада вазифасы эләкте.* А.Вергазов

24) *күч.* Дәрестә берәр төрле билге алу. --- *мин --- Рафаилдән: – Математикадан ничек барасың соң, үзләштереп буламы? Ничәлеләр алгалыйсың? – дип сорадым. – Төрлечә була, абый, күбесенчә дүртле, сирәк кенә бишлесе дә эләккәли.* Г.Сәгыйров

**Эләгә башлау** Эләгергә тотыну. *Тегенди-мондый чир эләгә башласа, аның дәвасы билгеле иде: бер стакан аракы.* М.Мәһдиев. *«Тукта инде, балык эләгә башлады бит, тагын бераз гына утырыйм», – дип, ул кайту ниятеннән баш тартты ---.* Г.Гыйльманов

**Эләгә язу** Аздан эләкми калу. *Ул үзе ике тапкыр эләгә язып, бер әрмән карчыгы ярдәме белән чак котылып кала алды.* Г.Ибраһимов. *Тракторның чокыр-чакырларны акрынаймыйча үтүендә, артына тагылган культиваторларының тимер капкага эләгә язып дөбер-шатыр керүендә үк ниндидер ярсу сизелде.* Ф.Садриев

**Эләгеп бетү** Тәмам, тулысы белән, барысы да эләгү. *Тирә-юньдәге бөтен егет-җилән Фәндәсәнең магнит кырына эләгеп бетте бугай инде.* Д.Гыйсметдин. *Артур исемле малай ул, бөтен вагонны дер селкетә, холыксызрак, дөрес тәрбия эләгеп бетмәгән бугай.* Сөембикә

**Эләгеп калу** Эләккән хәлен саклау. *Яшел чүпрәк кисәге ботакка эләгеп калды.* Ф.Яруллин. *Миңа сугыш елларының да шаукымы эләгеп калды бит.* К.Тимбикова

**Эләгеп китү** Кинәт, аз гына эләгү. *Зур тизлек белән басу юлыннан чапкан комбайнның бер канаты яр буендагы машинаның әрҗәсе кырыена эләгеп китте.* З.Хөснияр. *Болытлар Каманың ике ягы буйлап үскән наратларның очларына эләгеп-эләгеп китәләр.* Казан утлары

**Эләгеп тору** Еш кына, әледән-әле, даими эләгү. *Шул паспорт белән ерак юлга чыккан мөритләр еш кына полиция участокларына эләгеп торганнар.* М.Мәһдиев. *Лотерея билетларының да гел отышлылары гына эләгеп тора.* А.Хәсәнов

**ЭЛӘКТЕРГЕЧЛЕ** *с.* Каптырмалы, каптырмасы булган. *[Шакир картның] билендә бик яссы, прәшкәсендә икеме-дүртме эләктергечле таза каеш.* М.Мәһдиев

**ЭЛӘКТЕРМӘ** *с. сир.* Электерү өчен җайлашкан. *Лианаларның һавада эләктермә тамырлары --- – үсемлекләргә аерым бер шартларда яшәргә мөмкинлек бирүгә яраклашып үзгәргән тамырлар.* Ботаника

**ЭЛӘКТЕРМӘЛЕ** *с.* 1) Эләктергече, эләктермәсе булган. *Зәкәрҗан сугыштан --- бер орден, дүртләп медальне бик яхшы офицерский френчкә тагып, билне яссы, ике эләктермәле офицер каешы белән буып --- кайтты.* М.Мәһдиев

2) Эләктереп куелган. *Костюмы эләктермәле*

**ЭЛӘКТЕРҮ** *ф.* 1) Тотып алу, тырнак, кул, томшык белән яки кыскыч, каптыргыч кебек корал белән тоту. *Мөнирә кыйпылчыкның кытыршы кырыеннан пинцеты белән җайлы гына эләктерде дә бер тартуда суырып та алды.* Г.Әпсәләмов. *Томшыклары нык, кырыйлары тешсыман, алар ярдәмендә каз үсемлекләрнең яфракларын һәм сабакларын кисеп ала, ә томшык очындагы тырнагы белән бөртекләрне эләктерә.* Биология

2) Нык тота торган нәрсә белән каптыру, тоташтыру, кадау, бәйләү, тагу; беркетү. *Мостафин --- йолдыз аеллы каешын тыгызлабрак эләктерде.* Х.Камалов

3) Төймәләрен яки каптырмаларын каптырып ябу. *Аягында ак оек, чалбары да яңа, --- күлмәге дә буй-буй, озын җиңен каптырган, күлмәк якасының өстәге бер төймәсе эләктермәгән.* А.Гыйләҗев. *Ул баскычтан төшә-төшә киенде, сәдәфләрен эләктерде һәм, арткы ишектән чыгып, китапханәгә йөгерде.* Ф.Садриев

4) Тешләү. *Этләр абалап өрә-өрә чыршыны камап алдылар, иң алдан чапкан чуар эт Бибинурның үкчәсен эләктереп тә алды.* А.Гыйләҗев. *--- качып баручы бүре, бастырып килүче Алабайга таба кинәт борылып, бугазыннан эләктерде.* Р.Батулла

5) Берәр нәрсә белән элеп алу, күтәрү, кузгату. *--- сәнәк тешләре камераның киң өлешендә салам порцияләрен эләктереп алалар ---.* Урып җыю машиналары

6) Тиз генә тотып алырга өлгерү, кискен, ашыгыч хәрәкәт белән каптырып алу. *Ул, урыныннан сикереп торып, автоматын эләктерде дә аланга таба йөгерә башлады.* Г.Әпсәләмов. *Ленарны, көпшәк кардан бата-бата инеш ярыннан менеп барганда, якасыннан эләктереп алдым.* Н.Хәсәнов

7) Төшеп барганда тотып алу; егылырга, аварга бирмәү. *Тупны һавада эләктереп алу*

8) Аулау, тоту, каптыру. *Кармак белән балыкны шәп эләктерә Илдус ---.* Н.Гыйматдинова. *Бераз киткәч, борылып карыйм – йомран тагын башын калкыткан. Ат кылыннан ясаган тозак белән бер эләктерермен әле үзен!* М.Галиев

9) Ялгыш орыну, тию, бәрү. *Сыер ---, арт аягы белән эләктереп, сөтле чиләгеңне аударып җибәрергә дә күп сорамый. Шулай берничә мәртәбә сөт түккәнем дә булды.* Ш.Җиһангирова. *Пароходка утырганда, сезне бер турист биштәре белән эләктереп киткән иде, сез аңа берничә тупас сүз кычкырып калдыгыз.* Сөембикә

10) Сугып, бәреп, атып тидерү, билгеле урынга туры китерү. *Ул томыргач, кайсыбызга килеп тисә, агачны шул кешедән китерттерә. --- Миңа да өч тапкыр эләктерде.* В.Нуруллин

11) Кулга төшерү, табу, алу. *Күрәм, син хатыныңнан «командировкага» киткәнсең, --- кызның шәбен эләктергәнсең.* М.Галиев. *Лимон сызгырып куйды: – Кайдан эләктердегез бу малны?* Р.Зәйдулла

12) Үзләштерү, үзенә алу. *Хәмитов белән туганлашырга, квартирның шәбен эләктереп, зур кешеләр белән аралашып гомер сөрү синең ният.* Ә.Баян. *Тәхетне эләктереп алган Талиб исә кайчандыр ил терәге булып торган Борак турында баш ватудан бөтенләй туктаган ---.* В.Имамов

13) *сөйл.* Кулга алу, тоту. *Бүген исә Сакмар буенда язгы ташу ярга чыгарып аткан бүрәнәләрне җыеп мәшәләнгәндә, аны кызыллар килеп эләктерде.* Ф.Сафин. *Ничек инде елмаймасын – утлы коралны чормада яшереп саклаучы бандаңы кулга эләктерде ләбаса.* Т.Миңнуллин

14) *сөйл.* Тиз генә үзең белән алу. *– Егетләр, бәрәңге суына, килегез! – диде ул, шат тавыш белән. --- Зиннәт ике бәрәңге эләктерде дә, һай-һайлап, аты янына чапты.* Н.Гыйматдинова. *Чәй эчәргә утыргач, шикәр савытыннан бер кисәк шикәр эләктерде дә шкаф түбәсенә менеп кунаклады.* Балачак китабым

15) Урлау, урлап китү. *[Әлхамгали] көзен Эстәрлетамакта баржаларга иген төягәндә, берничә капчык бодай-*

*ның (кай арада эләктерәләр диген!) юк булганын «күрми дә кала».* З.Зәйнуллин. *Әле күптән түгел анын, унсигез миллиард сум эләктереп, гаиләсе белән АКШка чыгып таюы матбугатта хәбәр ителде.* Т.Нәҗмиев

16) Нәрсәне дә булса аз гына алу. *Иртән бал калагы очына эләктереп шикәр комы, күз алдар өчен генә чәй бөртекләре йөгерткән кайнар су һәм биш йөз грамм ипи бирәләр Черек күлдә.* А.Гыйләҗев. *Тизрәк ботка ашыйсылары килә. --- менә Таифә әбиләре, кашык очына эләктереп, бер тапкыр кабып та карады.* Ф.Хатипов

17) Сугу; кыйнау. *Йодрыгы нык икән каһәрнең – шәп эләктерде. Чак кына авып китмичә калды Равил.* В.Нуруллин. *Дөрес, [улымның] арт ягына эләктергәнем бар, анысы да – өч тапкыр әйтеп тә тыңламаганда.* Юлдаш

18) Үзе белән алып китү, алып бару, ияртү. *Күркә Гариф белән Негр Карахмәтне дә үзеңнән калдырма. Шәүкине дә эләктер!* Л.Лерон. *Безгә килегез, балаларны да эләктерегез*

19) Табуы, алуы бик кыен булган нәрсәне тиз арада, оста итеп яки җиңел генә кулга төшерү. *--- балалар бакчасына тәрбияче булып урнашты да куйды, --- тулай торактан бер бүлмә дә эләктерде.* Г.Әдһәм

20) Берәрсе башлаган яки төгәлли алмаган сүзне, эш-гамәлне күтәреп алу, дәвам итү. *– Ә бит көзләр җитте, көзләр, – ди Фәния. – Моңсуланмасана, – дип эләктереп ала Нурфия.* Н.Гыйматдинова. *Җырның көен үзе шыңшып та күрсәтте. Гармунчы аны шунда ук эләктереп тә алды.* Р.Гарипов

21) *сөйл.* Фаш итү, ялганын тоту. *Жандарм белән тоткын арасында бер-берсен алдау, бер-берсен эләктерү исәбе белән ялшерен көрәш башланды.* Г.Ибраһимов

22) Җәза бирү, шелтә белдерү. *Рәис иң шәп ике сыерны сатты. --- Әйткән өстенә. Аңа шуның өчен эләктерде Давыл.* Н.Гыйматдинова. *Ярый, ярый, көтүне тараткан өчен эләктермәбез үзеңә ---.* Р.Вәлиев

23) *куч.* Тиз генә кию. *Бәлки, су төшкәндер дип, аякка галош кына эләктергән идем.* Р.Мулланурова. *Ул [Хәдичә] ничек кирәк алай өстенә бишмәт эләктереп, яланаяк ишегалдына йөгереп чыкты да саумаган сыерын, зарыккан сарыкларын урамга куып чыгарды.* М.Маликова

24) *күч.* Берәр төрле белем алу. *[Синең Гөлгенәңнең] бүген имтиханга кереп китүе булды, мин борчылырга да өлгермәдем, бишлене эләктереп тә чыкты!* Ә.Сафиуллин

25) *күч.* Алу, йоктыру. *Тиф эләктереп, үпкәсе шешеп кайтып егыла, айга якын үлем белән яшәү арасында тартыша.* Р.Мулланурова. *[Миңзифа:] Улым, төнлә ялгызың йөри күрмә, урам фахишәләренә эләгеп харап булырсың. СПИД эләктерерсең, Алла сакласын.* И.Юзеев. *Заманында Төркестан якларыннан эләктереп кайткан малярия зәхмәте дә үзен сиздерә башлады, хәерсез.* Р.Низамиев

26) *күч.* Берәр йогынты ясау, берәр нәрсә тәэсиренә тоту (тәнкыйть, көлке һ.б. тур.). *Фельетонга эләктерү*

◊ **Эләктереп (кенә) алу** 1) Берәр сүзне, эшне сылтау итеп, шуның иясенә бәйләнү, каныгу. *Аның бу сүзләрен Нурулла эләктереп кенә алды: – Ә-ә-ә, димәк, ул көче белән масая, шулаймы?* Ф.Садриев; 2) Бик тиз, бик теләп кушылу, хуплап каршы алу. *--- таң атуга, беренче булып безнең әтәч --- аваз сала. Аның тавышын күрше әтәче эләктереп ала.* М.Галиев

**Эләктерә башлау** Эләктерергә тотыну. *Урамнан гына түгел, эш вакытында да кинотеатрда утыручыларны да эләктерә башладылар.* Н.Акмал. *Көн кичкә авышкан, авызларына бер валчык кермәгән студентлар, авыл урамнарыннан барганда, коймадан иелгән алмагач ботакларындагы кып-кызыл алмаларны эләктерә башладылар.* Х.Ширмән

**Эләктерә язу** Аздан эләктерми калу. *Шулчак, каян килгәндер үземә шундый ният, чөелгән ипигә сикергән эт кебек авызымны ачтым да, әбинең бармагын эләктерә язып, тешләремне шакылдаттым.* Ф.Баттал. *Әнә бит, Шайтан буенда үзен дә, бер солдатны да әҗәлнең үлем тырнагы эләктерә язган иде.* С.Шәрипов

**Эләктереп алу** Тиз генә эләктерү. *Сәях малайны каткан бармаклары белән эләктереп ала да үзенә тарта.* Х.Камалов. *Явыз челән ике аягына баскан да бакаларны озын томшыгы белән һавага чөя, аннан эләктереп алып йотып җибәрә.* Т.Шакирова

**Эләктереп бирү** Эләктерергә ярдәм итү

**Эләктереп калу** Эләктерергә өлгерү. *Моны Әлтәфи үзе дә белми иде, Усман Әлмиевне аның күргәне дә юк иде, ул бервакыт шәһәрдән туганнарының бу турыда сөйләшкәнен үзенең сизгер, җитез колагына эләктереп кенә калган иде.* М.Мәһдиев. *--- елгыррак кызлар, малайлар буразналарга тәгәрәгән кукәйләрне эләктереп калырга ашыгалар.* А.Гыйләҗев

**Эләктереп кую** Эләккән хәлгә китерү. *Ялтыравык каптырма белән эләктереп куйган бөдрә чәче дә, очлары күккә чөелгән нәзек кашлары да --- аны әкияти патша кызына охшата.* А.Әхмәтгалиева. *--- акчаны Сөмбеләнең кытыгы килә торган иң сизгер төшенә – култык астындагы кесә төбенә булавка белән эләктереп куйды.* К.Кәримов

**Эләктереп тору** Еш кына, әледән-әле, даими эләктерү. *Моның ише чапкыннарны сәгать саен диярлек эләктереп торалар, әмма --- аларның берсе дә асыл кошка тиңләрлек табыш булып чыкмый.* В.Имамов

**ЭЛӘ́-ТАНАК** *и.* Берәр предмет, күренеш, процессның әйбәт, гадәти, нормаль хәле, торышы, барышы; рәт, рәт-чират. *Фәйрүзә кайчандыр салам эскертләре салып йөргән бодай җирләренең элә-танагы калмаган, казылыптырмачланып беткән.* Г.Ахунов. *Үз тормышларының башта элә-танагы булмады.* М.Мәһдиев

**ЭЛӘ́-ТАНАКСЫЗ** *с. сөйл.* 1) Таушалган, тузган, искергән. *Өсте элә-танаксыз, яулык читләреннән чәчләре тузгып чыккан, кулында шакшы су чиләге.* Ф.Хөсни. *Ләйлә турында уйлый башласа, сугыштан кайткач та, ачлыкның иң куркыныч чагында күренгәнчә, элә-танаксыз сәләмә киеме, тузгыган чәчләре арасыннан хәтәр елтыраган шомлы күзләре белән каршысына килә дә баса...* Г.Бәширов

2) Ямьсез, җыйнаксыз; ялкау, булдыксыз. *[Зәйтүнә:] Әйт идең, ичмаса, яманла идең: карточкада гына шундый, тормышта элә-танаксыз ул, диген идең.* Х.Вахит

**ЭЛГӘК** *и. диал. к.* **элмәк** (*1, 5 мәгъ.*). *Башларыбызга чәчәкләрдән кыршау ясап кидек. Минем элгәкләремә, кесәләремә, тирәләй итек кунычларыма тездек.* М.Фәйзи

**ЭЛГӘР** *и.* 1) Башлангыч бирүче, башлап җибәрүче, аерым бер өлкәдә нигез салучы. *Идел буе болгарларының элгәрләреннән берсе сармат кабиләләре булуын искә төшерсәк, төрле гасырларда сармат кабиләләренең галәмәт киң территорияләрдә яшәгәнлеге кабат раслана.* Мирас

2) *а.х.* Кырны башка берәр культура чәчелгәнгә кадәр биләгән үсемлек.

*Туфрак яхшы дымланганда, уҗым культуралары теләсә кайсы элгәрдән соң тулы һәм бердәм шытымнар бирәләр.* Чәчү әйләнешләре – игенчелекнең нигезе

**ЭЛГӘРЕ** *рәв. к.* **элек**. *Шулай да бу куанычны Газиз алдына вакытыннан элгәре җәеп салу ярамый иде әле.* Г.Бәширов. *– Элгәре үзең барып төплән әле, аннары күз күрер, – диде [Һадия].* М.Галиев. *Элгәрерәк, колхоз чыккан дәвердә, комсомоллар гел шулай җырлап эшлиләр иде.* Ф.Яхин

**ЭЛГӘРЕГЕ** *рәв. к.* **элекке**. *Бу сугышны бетерәм дә, авылга кайтып, яңа дөнья көтә башлыйм, элгәреге үчне кайтарам: боярдан басып алган җирләрне мамык кебек йомшартып, кадерләп сөрәм, --- ди торган иде.* Г.Ибраһимов. *Зөһрә апа, элгәреге үпкәләрен онытып: – Бу киемнәрең бигрәк килешә икән, улым! – дип, улының иңбашларын, күкрәкләрен сыйпады.* А.Гыйләҗев

**ЭЛГӘРЕ́ЧӘ** *рәв. к.* **элеккечә**. *Гарәп мөселманнары элгәречә җиде катынга үләнәләр микән, Мәчтүрә астаем?* Н.Гыйматдинова. *Камыш кыштырдавын элгәречә яхшыга юрыйсы килә.* Сөембикә

**ЭЛГӘШҮ** *ф.* Берәр җиргә вакытында барып җитешү, соңга калмау; нинди дә булса эш эшләргә өлгерү; берәр хәлгә ирешү. *[Гәрәй] таң алдыннан гына өйләренә кайтып элгәште.* А.Гыйләҗев. *Франциягә барып элгәшкән, дип ишеттем мин аны.* З.Фәтхетдинов

**ЭЛГЕЧ** *и.* 1) Өс яки баш киемнәрен элү өчен чөйләр кагылган киштә. *Шүрлекләрдә, элгечләрдә әллә ниткән киемнәр: япон курткалары, герман костюмнары, әфган бутыйлары, Польша свитерлары, тагын әллә ниләр бар иде.* М.Мәһдиев // Шуның аерым бер чөе; ыргак. *Ул элгечләрдә, кечке сменада укучы балалар киемнәре белән беррәттән, шинельләр эленеп тора.* Ф.Хөсни

2) Өс киеменең иңнәрен кидереп элү өчен, каты материалдан ясалган җайланма, җилкәлек. *Шифоньер ишеге шар ачык, элгечтә аның берничә күлмәгеннән башка кием-салым күренми ---.* Р.Вәлиев. *Мөршидә апа элгечтән күлмәк сайлый: берсен ала, берсен куя, тәмам каушады.* Н.Гыйматдинова

3) Элеп кую өчен киемгә тегелгән элмәк. *[Мидхәт]: Карале, бу пальто нишләп эленми соң, ә?! Элгече өзелгәнме соң моның?* Х.Ибраһим. *Җепне сапладым тагын, Бетердем элгеч тагып.* В.Хәйруллина

4) Ишек, капка бикли торган ыргак яки бер башы күчәргә беркетелгән пластина; келә, бик. *Мохтар, ишек элгечен ычкындырып, ишекне ачты.* Ш.Камал. *Бераздан аның келәт ишегенең элгечен эчтән төшереп бикләгәнен ишетеп калам.* Ф.Хөсни. *Капка элгеченең чылтырап ачылуына кадәр элеккечә икән бит!* М.Галиев

**ЭЛДЕРТҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **элдерү**

2) *сөйл.* Бик тиз йөрү, тиз йөгерү, чабу, җиңел адымнар белән кызу бару. *Агайның юртагы шундый шәп элдертә...* Г.Бәширов. *Моны ишетүгә хәбәрче, күп уйлап тормастан, кибеткә элдертте.* З.Фәйзи. *Таза егет анысын куа ук китте. Ләкин теге каты элдертте.* М.Мәһдиев

3) Бик кызу йөрү (транспорт тур.). *Кузгалдылар. Машина элдертә генә.* Ф.Яхин

4) Өнәп бетермичә, көнләшеп яки башкача бәяләп сөйләгәндә, кемнеңдер берәр транспортта утырып йөрүен белдерү өчен кулланыла; чабу, җилдерү. *Машиналарда гына элдертү*

5) *сөйл.* Тиз генә, аннан-моннан гына, теләсә нәрсә кию; элү (*7 мәгъ.*) *Әмма бала, әйтерсең лә бу шыксыз салкыннан котылу юлын күргән төсле, яланаякка элдерткән каталарын ләштердәтә-ләштердәтә, түбән очка таба йөгерде.* Г.Ибраһимов

**Элдертә башлау** Элдертергә тотыну. *Халык арасыннан әкрен генә юл ярып барган троллейбус, Ленин күперен үтеп дамбага чыккач, бик кызу элдертә башлады.* М.Маликова. *Шәһәр читендә машинабыз кызурак элдертә башлады.* М.Әмирханов

**Элдертә бирү** Бернигә дә карамыйча элдертү. *– Әйдә, элдертә бир, телеңә күп салышма, – [диде Зариф].* М.Хәбибуллин. *Мәсгуть исә, күңеле һәм тәне бушлыктан иңнәрендә канатлар тойгандай, «Ленд Краузер»ында элдертә бирде.* Ф.Яхин

**Элдертеп китү** Кинәт кенә элдертә башлау. *Суфия тулы вагонетканы элдертеп китте.* М.Рафиков

**ЭЛДЕРҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **элү**. *--- директорыбызның талканы коры: андыйларны мәктәптән куу турында көнендә үк боерык яздырып элдерә.* Г.Галиев. *Балаң булмаса, алар караватың янына бишек элдерә, үлем түшәгендә ятканда дога укыта яки әллә кайчан онытткан җырыңны искә төшерә.* Т.Миңнуллин

2) *сөйл. к.* **элдертү** (*2, 3 мәгъ.*). *Тотыш углан, җилдәй очып, капкадан, күпердән чыкты да басу ягына элдерде.* Н.Фәттах. *Җил кебек җилдереп барган уты сүндерелгән мотоцикл, авыл урамын чыгып, басу юлыннан элдерде.* Г.Галиев. *– Бу көннәрдә күп элдердегез. Житешеп булмый артыгыздан, – дип, Юнысов юлын дәвам итте.* Язмышлар яңарганда

3) *сөйл.* Берәр эштә, өлкәдә нык алга чыгу, башкалар җитә алмаслык дәрәҗәдә алга китү. *Бераздан соң халык гөр итеп: «Булмады инде, чаптар ташлады, чаптар элдерде!»* М.Гафури

4) Нәрсәгә булса да ут үрләтеп җибәрү, кабызу. *Шырпы да сыздылар. Шапырай карт ашыкмыйча гына элдерде.* М.Хәсәнов. *Ул кесәсендә изелеп беткән каптан сигарет алып авызына кыстырды, шактый гына аңа ут элдерә алмыйча азапланды.* Р.Зәйдулла

5) *сөйл.* Тиз аңлап алу, алга табан җиңел өйрәнү. *Мин русчаны бик тиз элдереп алдым.* Х.Сарьян

6) *сөйл.* Берәр эшне тиз эшләү. *Әпипәгә бию ансат. Анысын элдерәм генә.* Ә.Бикчәнтәева

7) Тиз генә тотып алырга өлгерү, ашыгып кына алу; эләктерү (*6 мәгъ.*). *Малай сикереп торган уңайга бер-ике коймакны элдерде дә, томырылып, баскычтан урамга атылды.* А.Гыйләҗев

8) *күч.* Сугу. *[Инсаф] бер көнне йөзе җимерелеп кайтып керде. Трамвайда бер хатын-кызга төчеләнгәндә элдергәннәр үзенә.* Ә.Моталлапов

◊ **Элдереп алу** *к.* **элеп алу** (*2 мәгъ.*). *– Белмәгәч, нигә белергә тырышмадыгыз! – дип элдереп алды Рәшат.* А.Гыйләҗев. *Гамилнең энесе шундук элдереп алды: – Тозлы диңгезгә мин дә барам!* А.Тимергалин

**Элдерә башлау** Элдерергә керешү. *Болай булса, эшләр җайлана: тагы берәр атнадан юллар кибәр дә велосипедка гына утырып элдерә башлармын, дип, аеруча рухланып йөргән иде.* В.Нуруллин. *Көтүчеләр янныннан чыгып, олы юлга төшкәч, Мәсәви баба таягын җәя сыман итеп аркасына асты да, ике кулын селтәп, җиңел генә элдерә башлады.* Н.Фәттах

**Элдерә бирү** Бернигә игътибар итми генә элдерү. *Машина асфальт юлдан җиңел генә элдерә бирә.* М.Хәсәнов

**Элдереп җибәрү** Тиз генә элдерү. *Сәкеләр күренде, сәке баганасында китек куыклы лампа да бар икән, ут элдереп җибәрде.* Х.Камалов. *Бәхеткә, аралыкта утынга дигән бер-ике такта кисәге, әз-мәз салам да бар иде, егет,*

*шуларны тутырып, ут элдереп җибәрде.* А.Әхмәтгалиева

**Элдереп калу** Элдерергә өлгерү. *Китә күңелле әүмәкләшү, рәхәт чырчу, өлкәннәр кукәй элдереп калган уңган балаларның башларыннан сыйпап сөенешәләр.* А.Гыйләҗев. *Шоферы --- кабинадан төшкәндә ук: – Иптәш Шәрәфиев, энем, ярый әле алданрак элдереп калдың. Чатта бәрелешә идек бит!* Т.Нәҗмиев

**Элдереп китү** Кинәт кенә элдерү. *Ә Казан каласында урамдагы колонка суларына сироп кушып, стаканын өч тиеннән саталар иде, дип элдереп китә Фазыл...* К.Кәримов. *Янчурин байталына менде. Фуражкасын басыбрак киеп, портупеясын төзәтте, елтыр хром итекләрендәге шпораларын кыскалап, җиңел генә элдереп китте.* Ш.Шәйдуллин

**ЭЛЕВА́ТОР** *и. лат.* 1) Зур күләмдә ашлык кабул итү, чистарту, киптерү, саклау, үлчәү һәм җибәрү корылмалары комплексы. *Алда, аксыл рәшә эчендә, Бөгелмәнең биек таш йортлары, элеваторы --- күренде.* Г.Әпсәләмов. *Олаулар, аны [Исхакны] пристань юлы чатында калдырып, акрын гына элеватор ягына элдерделәр.* А.Гыйләҗев

2) Гомумән зур күләмдә сибелүчән йөкләр саклау корылмасы

3) *махс.* Йөкләрне, гадәттә данәле яки чәчелүчәннәрне, бер урыннан икенче урынга күчерү җайланмасы, транспортёр. *Һаҗәр белән буровой эшчесе бушаган элеваторны рәтләп эләктерергә дә өлгерә алмадылар, «давай, давай!» дип дуамалланып, куалап торган Минһаҗ лебёдканы өченче тизлеккә җибәрде.* М.Хәсәнов

4) Су белән җылыту системасында эссе һәм салкын суны кушу өчен кулланыла торган су агынтылы насос

5) *мед.* Теш суырып алу коралы, каргаборын

**ЭЛЕГАНТ** *с. кит.* 1) Нәфис, матур, нәзакәтле, күркәм. *Гаҗәп элегант бу киемнәр җайлы-уңайлы һәм бер үк вакытта тыйнак-нәфис тә.* Асылъяр. *Бил дә ачылып йөрми, җылы, уңайлы һәм элегант модель.* Кәеф ничек?

2) Зәвык белән киенгән, купшы, көяз, үзен бик нәзакәтле тота торган. *Камил Әхмәтович бүген аңа сөйкемле, элегант, чын рыцарь булып күренә.* Г.Әдһәмова. *Рәмзия каршысында --- җирән чәчле ир-атны күреп гаҗәпләнде. Бу юлы ул тагын да җыйнаграк һәм элегант күренә иде.* Ф.Галиев

**ЭЛЕГАНТЛЫК** *и.* Нәфислек, көязлек, купшылык, элегант булу сыйфаты. [*Каринның*] *киенүендә нindидер үзенә күрә элегантлык, кәрбәзлек, хәрәкәтендә салмак сынлылык, әмма эшләпә киюендә аерым бер чибәрлек бар иде.* Б.Урманче

**ЭЛЕ́ГИК** *с. кит.* 1) Элегия билгеләре булган; элегия төренә караган. *XIV гасырда үзбәк поэзиясе күп төрле яңа формаларга (лирик һәм эпик поэзия, элегик шигырьләр, дастаннар, мемуарлар жанры һ.б.) байый.* К.Гыйззәтов. *Элегик поэма*

2) Моңсу, уйчан, сагышлы, хыялый; кайгылы. *«Матрос Штепенко» балладасы гомумән үзенең музыкасы, элегик моңы белән көйле.* Г.Кашшаф. *Мәрсияләр өчен, кагыйдә буларак, элегик, кайгылы аһәң дә хас.* Х.Миңнегулов

**ЭЛЕГИСТ** *и. рус* Элегияләр язучы шагыйрь

**ЭЛЕ́ГИЯ** *и. гр.* 1) *әд.* Моңсу, сагышлы, уйчан яки хыялый кәефне тасвирлый торган лирик жанр һәм шул жанрда язылган әсәр. *Ода-мәдхияләр, --- элегияләр, --- эпиграммалар, җырлар – эчтәлек буенча да, төзелешләре буенча да билгеле бер тотрыклылыкларын саклаган лирик җырлар – һаман да туа торалар.* Н.Юзиев. --- *Тукай элегиягә охшаган шигырьләр дә язган, әмма боларда да күзгә бәрелерлек өметсезлек, пессимизм сизелми.* Г.Баттал

2) *муз.* Сагышлы, моңлы вокаль яки инструменталь әсәр

3) *иск. күч.* Моң, сагыш, эч пошу, күңел төшенкелеге

**ЭЛЕК** *рәв.* 1) Нинди дә булса вакыттан алда, иртәрәк. *Моннан дүрт ел элек кияүдә булуының ни дигән сүз икәнлеге турында да аңлашмадык.* М.Әмир. *Безнең шәһәрдә моннан берничә ай элек кенә күренә башлаган бу аксак һәм чукрак карт пышылдап сөйләшкәнне ничек ишетә ала икән?* А.Шамов

2) Башка берәүдән алдарак. *Илне саклау өчен чакыру килсә, Беләм, мин беренче барсам, Син миннән дә элек барырсың.* Һ.Такташ. *Кабаланып, кешедән элек кабергә барып керде.* И.Гази

3) Башта, нинди дә булса бер эштән алдан, әүвәл, беренче эш итеп. *Әнкәй безне Сөннән алып кайткан, Сөн суында юган иң элек.* Р.Миңнуллин

4) Беренче чиратта, башта. --- *күп бәхәсләшә торгач, эшне иң элек ишле гаиләле, үзе үк балта остасы Хифасулла карттан башларга булдылар.* А.Гыйләҗев. *Кытай термосыннан булары чыгып торган кайнар чәй агызып, иң элек миңа бирә.* М.Галиев. *Казанга килгәч, иң элек институтка барып, документларын тапшырды ул.* М.Маликова

5) Әүвәл заманда, башлангыч дәвердә. *Элек безнең җилкәдә үз алпавытларыбыз белән үз чиновникларыбыз гына утыралар иде.* А.Шамов

6) Моннан күп еллар алда. *Элек заманда бер солдат, озак кына хезмәт итеп, өенә кайтып бара икән.* Әкият. *Элек, кичке авыл тынлыгында, еракта өреп куйган эт тавышлары үзе бер моң булып ишетелә иде.* М.Галиев

**ЭЛЕККЕ** *с.* **1.** 1) Моннан күпмедер еллар элек булган, күптәнге, иске. *Юк, бу инде элекке Идел генә түгел икән, бу хәзер Бөек Идел дип атала икән, анда хәзер диңгез пароходлары йөри икән!* Г.Бәширов. *«Ник алай рәнҗетәсең мине?» – дип әйтә алмады килен, чөнки ул элекке гадәт буенча тел яшерә иде.* М.Маликова

2) Хәзергедән алда булган, моңа кадәрге. *Габдулла хәзер, элекке килүендәге сыман, кешеләргә исе китеп карамый, киресенчә, алар – аның гади, күптәнге танышлары.* Ә.Фәйзи. *Мондый кичәләр күркәм бер гадәт булып киткәнлектән, аларда мәктәпнең барлык элекке укучылары да катнашырга тырыша ---.* Г.Әпсәләмов

3) Баштагы, үткәндәгесе кебек үк; шул ук, шундый ук. *Кайтсам да, элекке күк каршы алмаслар, дип уйладым.* Ф.Хөсни. *Гөлкәй брезент җәймәне арбаның арткы ягына җыеп салган, уртага элекке кебек коры печән тутырган.* Х.Ширмән

**2. элеккеләр** *и. мәгъ. күпл.* Ата-бабалар, борынгылар; тормыш тәҗрибәсе булган кешеләр. *Камил уянганда инде кояш, элеккеләр әйтмешли, тәртә буе күтәрелгән иде.* М.Галиев. *Элеккеләр белми әйтмәгәннәр.* Р.Габделхакова

**ЭЛЕККЕГЕ** *с. ялг. к.* **элекке**. *Һәм болар барысы да икенче көнне – атны иртәгә яңа абзарга, элеккеге урынына күчерәсе дигән көнне ачылды.* Г.Гобәй. *Элеккеге эш тәҗрибәсе буенча ул Гомәрне ачуланырга тиеш икәнен тоя, ләкин нindидер эчке тоем, нindидер кешелекле җил аны ачуланудан кисәтә иде...* Г.Рәхим

**ЭЛЕККЕ́ЧӘ** *рәв.* Элекке кебек, искечә, баштагыча, элек булганча. *Элеккечә инде ул чиләкләп буза да эчә алмый, терсәгеннән майларын агызып симез итләр дә ашый алмый.* Н.Фәттах.

*Кыз шунда гына күзләрен ачты, бүлмә элеккечә караңгы иде.* Н.Гыйматдинова

**ЭЛЕКТӘ** *рәв.* 1) Күптән, кайчандыр, моннан беркадәр яки күп вакыт элек; әүвәл, борын заманда. *Галәветдин абзый ямщик булып, эшләп үскән, диләр, электә.* Ш.Маннур. *Электә дә татар хатын-кызлары арасында бирнәне арттырып мактау гадәте булган бит.* Г.Әпсәләмов

2) Башта ук, алдан. *Электә үзләрендә Мәккә белән Мәдинә сурәте генә бар иде, өйгә ямь бирә дип, базардан тагы зур ике шәмаил алдыртты.* Г.Ибраһимов. *Формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик булган татар культурасының күп кенә тармакларына ул нигез салган һәм электә салынган нигезләр өстенә беренче рәт бүрәнәләрне тезүче ул булган.* М.Галәү

**ЭЛЕКТӘГЕ** *с.* Үткән вакытлардагы, элек булган, үткәндәге. *Һаҗәр мине яратмавын электәге шикелле ачык күрсәтми һәм ачыктан-ачык кырын да тормый.* Ә.Еники. *Электәге кебек, үзеңне үзең белештермичә эшләү кыенайды.* И.Гази

**ЭЛЕКТӘГЕ́ЧӘ** *рәв.* Элеккечә, элек булган кебек, элек кабул ителгән, эшләнгән рәвештә. *Электәгечә иртәнге сәгать дүрттә урыныннан сикереп тора иде.* М.Мәһдиев. *Ул моннан миллион еллар электәгечә иген-үләннәргә шифалы яңгырлар яудыра, төнге гашыйклар өчен йолдызлар аттыра.* Р.Фәйзуллин

**ЭЛЕКТӘН** *рәв.* 1) Әллә кайчаннан бирле, бик күптәннән башлап. *Электән үк завод-фабрикалы Һәм эшлекле Казан идең син.* Ә.Исхак. *--- кешеләрнең табигать күренешләренә реалистик карашы электән килгән ышанулар белән берникадәр аралашып бара.* К.Гыйззәтов

2) Моннан күп еллар алда; элек (*6 мәгъ.*)

3) Башта ук, алдан. *Ул электән җитди булган чыраена бераз ачу билгесе чыгарып, кызның шаяртуына каршы шактый тупас җавап кайтарды.* М.Әмир. *--- суфи самавырны, шәкертләр ярдәме белән, мич янындагы электән хәзерләнеп куелган кирпечләр өстенә утыртты ---.* Ә.Фәйзи

4) Күптәннән бирле, һәрвакыт. *Әмма минем үзем өчен бу «морзалык» дигән нәрсә электән үк шактый караңгы, чуалчык бер мәсьәлә булып кала килде.* Ә.Еники. *Кайбер сүзләр электән бирле ике-өч, хәтта артыграк та исем белән аталып йөртелгәннәр ---.* А.Тимергалин

**ЭЛЕКТОРАТ** *җый. и. лат.* Парламент, муниципалитет, президент сайлауларында нинди дә булса сәяси партия яки кандидат өчен тавыш бирүче сайлаучыларның һәммәсе. *Һәрбер кандидат үзенең күпме электораты барлыгын белә һәм шуңа канәгать.* Р.Миңнуллин. *Кыскасы, хәергә тиеннәр өләшеп, өметләндереп, кирәк булса куркытып, безнең беркатлы электоратны кирәгенчә «эшкәрттеләр» дә, нәтиҗәләре алдан ук билгеле булган беренче сайлаулар узып та китте.* Н.Шәрифуллин

**ЭЛЕКТР** *и. гр.* 1) *физ.* Корылган кисәкчекләрнең (электрон, позитрон, протон һ.б.) юнәлешле хәрәкәтеннән гыйбарәт энергия формасы. *Атмосферада көчле электр бушанулары (яшеннәр) вакытында, яшен төрле корылмаларга, биналарга һ.б. сугарга мөмкин.* М.Зиннәтов. *Газларда һәм каты җисемнәрдә электр кыры тәэсирендә барлыкка килгән нурланыш электрик люминесценция дип атала.* Физика

2) Әлеге энергиянең халык хуҗалыгында һәм көнкүрештә файдаланыла торган формасы. *Үзебездә радиоузел корып җибәрсәк, яшелчә бакчасына яңгыр установкасы куйсак, сыерларны электр белән сава, сарыкларны электр белән кырка башласак ---.* Ә.Еники. *Күпләр, мичләренә утын якмыйча, өйне электр белән җылытырга тотындылар.* Т.Миңнуллин

3) Шул энергияне үткәрү, тарату өчен хезмәт иткән техник система. *Май бәйрәме алдыннан электр кертәләр, дип язганнар иде ич.* Н.Фәттах. *Тегермән буасында колхоз электростанциясенең әкрен генә гүелдәп эшләгәне ишетелә, электр керткән йортлардан кар өстенә нур көлтәләре сузылган.* М.Мәһдиев

4) Шул энергия ярдәмендә барлыкка килгән яктылык. *Карчык --- бөркәнгән чапанына ыграк төренеп һәм нидер мыгырдана-мыгырдана, аларны эчкә кертте дә йөгереп барып электрны кабызды.* Р.Вәлиев

**ЭЛЕКТРИЗА́ЦИЯ** *и. рус* 1) *физ.* Берәр җисемдә электр корылмасы барлыкка килү күренеше; электрлану

2) *мед.* Электр белән дәвалау ысулы

**ЭЛЕКТРИЗА́ЦИЯЛӘҮ** *ф. физ. мед.* Электризация ысулы белән дәвалау, электризация процедурасы үткәрү, электр йогынтысында тоту

**ЭЛЕ́КТРИК** I *и. рус* 1) *к.* **электротехник** I

2) Электр, электротехника белән эшләүче белгеч. *Менә әле генә электрикларны озаттым. Электрны өзеп торабыз.* А.Гыйләҗев. *Ә калганнары – күзгә-башка чалынмаган кешеләр: алары төрле төзү оешмаларының җитәкчеләре, сантехниклар, электриклар, телефонистлар ---.* М.Маликова

3) *иск.* Электр. *– Без дә авылга тиздән электрик керттербез, – ди.* Г.Толымбай. *Зур урамга чыкты, анда электрик бөтен дөньяны яктырта, урам тулы киенгән-ясанган кешеләр --- йөриләр.* Г.Ибраһимов

**ЭЛЕКТРИК** II *с.* Электр күренешенә нигезләнгән, шундый табигатьле; электротехника белән бәйле. *Имән агачының тамыры як-якка һәм бик тирәнгә тармакланып китә. Шуңа күрә аның электрик каршылыгы зур түгел.* Яшен

**ЭЛЕКТРИК** III *с. фр.* Зәңгәрсу соры, күксел соры. *Электрик төс*

**ЭЛЕКТРИКЛЫК** *и.* Электрик вазифасы, электрик эше. *– Дипломың булмаганга электриклыкка алганнардыр, – диде Таня апа.* М.Юныс

**ЭЛЕКТРИФИКА́ТОР** *и. рус* Электр үткәрүче, электрификация белән шөгыльләнүче белгеч

**ЭЛЕКТРИФИКА́ЦИЯ** *и. гр.-лат.* Электр энергиясен халык хуҗалыгының һәм көнкүрешнең төрле тармакларына кертү, электр энергиясе белән эшләүгә күчерү, электр үткәрү. *Механизация кертү өчен электрификация кирәк, электрификацияне булдыру өчен, гидростанция салырга кирәк.* Т.Гыйззәт. *Электр утлары кабындылар. Ленинның электрификация турындагы васыяте зур өлеш булып бишьеллыкка керде.* Г.Кутуй

**ЭЛЕКТРИФИКА́ЦИЯЛӘҮ** I *ф.* Электрификация үткәрү, электрлаштыру. *Сәнәгатьне электрификацияләү*

**Электрификацияләп бетерү** Электрификацияләүне тулысынча тәмамлау

**Электрификацияли башлау** Электрификацияләүгә керешү

**ЭЛЕКТРИФИКА́ЦИЯЛӘҮ** II *и.* Электрификация эше; электрификация процессы. *Инде 1920 елда ук В.И. Ленин Россияне электрификацияләү планын төзеде ---.* Дөньяда ниләр бар?

**ЭЛЕКТРИ́ЧКА** *и. рус сөйл.* 1) *иск.* Электрлаштырылган тимер юл

2) Шундый юлда йөри торган поезд; якын араларга, гадәттә шәһәр тирәсендә йөри торган поезд. *Бернечә*

*көннән --- ике дус электричка белән алтмыш чакрымдагы зур шәһәргә --- йөри башлыйлар.* М.Насыйбуллин. *Әле бакча сезоны башланмаган, электричкалар сирәк йөри.* Р.Мулланурова

**ЭЛЕ́КТРЛАНУ** *ф. төш. юн. к.* **электрлау**. *Без алда күреп узганча, ул атомнар капма-каршы корылмалар белән электрланганнар, шуңа күрә без ул кисәкчекләрне ионнар дип кенә атарбыз.* Р.Шаһморатова. *Аңардагы әчкәрге бер энергиядәнме, зал эче электрланган кебек тоелды бу мизгелдә...* Р.Низами. *Билгеле булганча, йон әйбергә ышкысаң, гәрәбә электрлана да вак салам кисәкләрен үзенә тартып, суырып ала башлый.* А.Тимергалин

**Электрланып бетү** Тулысынча электрлану

**Электрланып калу** Электрланган хәлгә килү. *Палатада һава электрланып калгандай тоелды ---. Сүзнең тәме бетте, уйлар чуалды.* Б.Камалов

**ЭЛЕ́КТРЛАУ** *ф. физ.* 1) Берәр җисемгә электр корылмасы бирү. *Ефәккә ышкып электрланган пыяла таякны ефәк җепкә эленгән җиңел бузина шарчыкка орындырып, аны электрларга мөмкин.* А.Пёрышкин

2) *сөйл. к.* **электрлаштыру**. *Шуннан инде халык тәмам кызган, Бөтен авыл белән кузгалып, Электрлап, мәңге туктамаслык Зур тегермән салган шул халык.* Г.Рәхим

**Электрлап чыгу** Һәрберсен электрлау

**ЭЛЕ́КТРЛАШТЫРУ** I *ф. к.* **электрификацияләү** I. *Белгән кадәресе – икесе дә тимер юлда эшлиләр, хәзер шәһәр яны юлларын электрлаштырып маташалар бугай...* А.Гыйләҗев. *Бельгия акционерлар җәмгыяте әле күптән түгел Казан трамвайларын электрлаштырды.* А.Расих

**Электрлаштыра башлау** Электрлаштырырга керешү. *МТС базасының Тазабанларда булуыннан файдаланып, авылны электрлаштыра башлады.* Г.Ахунов

**Электрлаштырып бетерү** Тулысынча электрлаштыру

**Электрлаштырып чыгу** Башыннан ахырына кадәр, барысын да электрлаштыру

**ЭЛЕ́КТРЛАШТЫРУ** II *и. к.* **электрификацияләү** II. *Ленин комсомолының шефы булган илне электрлаштыру планын үтәү нигезендә «Светогрэс» гигантын беренче майда ходка җибәрергә.* А.Алиш. *Авылларны электрлаштыру тарихын күп мәктәпләрдән язып җибәргәннәр.* Р.Зарипов

**ЭЛЕ́КТРЛАШУ** *ф. ялг.* 1) *к.* **электрлану**

2) *төш. юн. к.* **электрлаштыру**. *Барлык көндәлек тормыш кирәк-яраклары тулысынча электрлашкан булачак.* Р.Ишморатова. *Күрәсең, электрлашуның үзенең бик катлаулы тарихи чоры, ягъни бүгенге зур эшләрнең башлану чоры булгандыр.* Ш.Галиев

**ЭЛЕ́КТРЛЫ** *с.* 1) Электр үткәрелгән, электрлаштырылган; электр тоташтырылган. *Электрлы урындыкка гаепсез утыртылган.* Г.Кутуй. *Юлның сул ягында, урман буенда --- практик занятиеләр уздыру корылмалары. Электрлы, җылыткычлы берничә металл вагон.* Х.Камал

2) Электры булган, электр белән корылган. *Электрлы еланбалык*

3) *күч. кит.* Тәэсирле, үткен, көчле. *Якынайган саен Эшнең чигенә, Елмаюың агыла йөзеңә, Электрлы синең күз карашың.* Ф.Кәрим

**ЭЛЕ́КТРО-** *рус* Кушма сүзләрдә электрга мөнәсәбәтле булуны күрсәтә торган беренче кисәк: *электровоз, электрогитара*

**ЭЛЕКТРОАВТОМАТИЗА́ЦИЯ** *и. рус* Электр көче белән эшли торган автоматлар урнаштыру, электр көче белән эшли торган автоматлар системасы булдыру эше

**ЭЛЕКТРОАНА́ЛИЗ** *и. рус* Электролизга нигезләнгән, катнашма составындагы металларның микъдарын, электр үткәрүчәнлеген һ.б.ш.ны билгеләү өчен кулланыла торган химик анализ

**ЭЛЕКТРОАППАРАТУ́РА** *и. рус* Электр аппаратлары, контактлы электр челтәрендә эшли торган аппаратлар. *Акчасын хоббие – музыкага тотарга, ягъни электроаппаратура алырга планлаштыра.* Әлки таңнары

**ЭЛЕКТРОБИГУДИ** *и. рус* Электр челтәреннән эшли торган бигуди. *Термобигуди – электробигудиның «сеңелкәше», алар бары тик җылыну ысулы белән генә аерылып тора.* Юлдаш

**ЭЛЕКТРОБРИ́ТВА** *и. рус к.* **электропәке**. *[Латиф] үз бүлмәсендә электробритва белән сакал-мыегын кыра ---.* А.Расих. *Ул арада Алсу, ике кулына ике электробритва тотып, аны көтеп тора иде инде.* К.Кәримов

**ЭЛЕКТРОБУР** *и. рус тех.* Забойда тирән скважиналар тишү өчен кулланыла, электр двигателеннән эшли торган машина

**ЭЛЕКТРОВОЗ** *и. рус* Электр двигательле локомотив. *Әйе, моннан нәкъ кырык ел элек корымлы, йөрәк ярып кычкырта торган паровозларның пөхтә, ыспай һәм ялкау гына сызгыртучы электровозларга алыштырылганлыгын белми ---.* А.Хәлим. *Көчле прожекторлары белән тирә-якны елкылдатып торган мәһабәт электровоз сигнал биреп кузгалып китте.* М.Хәсәнов

**ЭЛЕКТРОГАСТРОГРА́ММА** *и. рус мед.* Ашказаны стенасы биопотенциаллары графигы

**ЭЛЕКТРОГИТА́РА** *и. рус* Тавышны динамикларга тапшыру көчәйткечләре булган, электр челтәреннән эшли торган гитара. *Электрогитара, гавот һәм барабан транзистор аша тирә-якка әрнүле ризасызлык тарата.* М.Юныс. *– Анда, ни, шәп инде, – диде Мансур. – Бишкаеннан кыллы квартет килгән. Шундый уйныйлар! Тик бигрәк тавыш – электрогитаралары белән колакны тондырдылар.* Т.Таһирова

**ЭЛЕКТРОД** *и. гр.* 1) *физ.* Электр кыры тудыру максаты белән электрон лампа эченә урнаштырылган пластинка, челтәрсыман үткәргеч. *Уңай электрод – анод, ә тискәре электрод катод була.* Физика. *Инглиз физиологы Джеймс Олдз, 50 нче елларда ук инде, күсе миенең кабык астына билгеле бер урынга электрод урнаштыра. Күсе, махсус педальгә басып, үз миенә ток импульсы бирә.* Кызыклы психология

2) Электр чылбырында аерым бүлемтекләрнең һәр ике очы

3) Электр белән эретеп ябыштыру җайланмасының эшкәртеләсе материалга ток биреп тора торган, гадәттә стержень рәвешендәге детале. *– Ярап тора инде, – диде Кәлимуллин һәм, өч япьле toткычка орчык буе яңа электрод беркетеп чүгәләгәч, яңадан битлеген йөзенә төшерде.* Р.Кәрами. *Ике туган сөйләшә-сөйләшә сварщиклар янына килде. – Сиңа монда электродлар белән мәшәкатьләнәсе юк.* Х.Мөхәммәтшин

**ЭЛЕКТРОДВИ́ГАТЕЛЬ** *и. рус* Электр двигателе, электр энергиясен механик энергиягә әверелдерә торган машина. *Моның өчен машина бүлегендә галәмәт зур күтәртү җайланмасы көйләнгән: ул барабаннан, аңа уралган озын корыч арканнан, электродвигатель һәм идарә итү пультыннан тора.* Ф.Зариф

**ЭЛЕКТРОДИАГНО́СТИКА** *и. рус мед.* Нервларның үткәрү һәм мускулларның кыскару сәләтен электр тогы ярдәмендә тикшерү ысулы

**ЭЛЕКТРОДИНА́МИК** *с.* Хәрәкәттәге электр корылмаларының үзара тәэсир итешүләренә бәйле, шул күренешләргә нигезләнгән. *Механикада гына түгел, электродинамикада да абсолют тикторыш булмый, --- анда механик һәм электродинамик законнар тигез дәрәҗәдә була.* Фән һәм тел

**ЭЛЕКТРОДИНА́МИКА** *и. рус* Физиканың хәрәкәттәге электр корылмаларының үзара тәэсир итешүләрен һәм үзлекләрен өйрәнә торган бүлеге. *Классик механика, классик электродинамика белән берлектә, хәзерге фәннитехник революциянең юнәлешен билгеләүче классик булмаган яңа фән баскычын тәшкил итә.* Фән һәм тел

**ЭЛЕКТРОДРЕЛЬ** *и. рус* Электр энергиясе ярдәмендә эшли торган тишү коралы, электр дреле. *Шәйхенур егетләре кулындагы үткен балталар кояшта елык-елык килә. Юналар, кисәләр, кадаклыйлар. Электродрельләр, парлашып, тургай кебек сайрыйлар...* А.Гыйләҗев

**ЭЛЕКТРОҖИҺАЗ** *и.* Электротехника җиһазлары. *Беркөнне, төнге сменада эшләгәндә, электроҗиһазларга әллә ни булды. Фараларны һич яндырып булмый. Мотор да киреләнә.* Р.Төхфәтуллин

**ЭЛЕКТРОИНЖЕНЕР** *и. рус* Электротехника инженеры. *Вюнсдорф лагерендагы хәрби әсир татарлар түбәндәге белгечлекләрне үзләштерәләр: парикмахер – 2 кеше, --- электротехник – 1, электроинженер – 1 --- кеше.* Казан утлары

**ЭЛЕКТРОЙОКЫ** *и.* Генератордан билгеле үзлекләргә ия булган электр тогын авыруның башына куелган электродларга җибәреп дәвалау ысулы. *Берничә ел элек дәвалауның яңа оригиналь ысулын – электройокы куллана башлагач, совет галимнәре бик кызык нәрсәләр күзәткәннәр.* В.Комаров

**ЭЛЕКТРОКАЛОРИ́ФЕР** *и. рус* Электр энергиясе ярдәмендә эшли торган калорифер; электр җылыткычы. *Салкын көннәрдә җылытырга тәрәзә асларына электрокалориферлар урнаштырылган.* А.Гыйләҗев

**ЭЛЕКТРОКАР** *и. рус* Аккумулятордан алынган электр энергиясе ярдәмендә хәрәкәт итә торган зур булмаган үзйөрешле йөк арбасы (заводларда, вокзалларда һ.б.ш. йөк транспорты чарасы буларак кулланыла). *Чиста асфальт юллардан деталь-узеллар ташыган электрокарлар --- тыз да быз чабышалар.* Н.Хәсәнов. *Рельслар өстендә дүрт тәгәрмәчле машина. Вокзалда посылка ташый торган электрокар шикелләрәк.* Х.Камалов

**ЭЛЕКТРОКАРДИОГРА́ММА** *и. рус мед.* Йөрәк тирбәнешенең электрокардиограф ярдәмендә эшләнгән график язмасы. *Башта Андрей Ивановичтан, аннары Плехановтан, иң актыктан Григорий Ивановичның үзеннән электрокардиограмма алдылар.* Г.Әпсәләмов. *Тугач та төшерелгән электрокардиограмма – ул бала сәламәтлегенең көзгесе.* Сөембикә

**ЭЛЕКТРОКАРДИО́ГРАФ** *и. рус мед.* Йөрәкнең биопотенциаллары тирбәнеше вакытында барлыкка килгән электр импульсларын язып бара торган электр приборы. *Автомобильләр гүя кечкенә сырхауханә: анда иярченле навигация, ингалятор, электрокардиограф, глюкометр, реанимация һәм акушерлык җыелмалары урнаштырылган.* Татарстан яшьләре

**ЭЛЕКТРОКАРДИОГРА́ФИЯ** *и. рус* Медицинада, ветеринария һәм экспериментал физиологиядә йөрәк мускуллары эшчәнлегенең биоэлектрик потенциалларын график язып алу юлы белән тикшерү ысулы. *Ангиокардиография, электрокардиография мәгълүматлары да зарарсыз. Профессор тасманы актыга күтәрде һәм вак-вак тешләрне күрсәтә башлады.* Г.Әпсәләмов

**ЭЛЕКТРОКЫРЫНГЫЧ** *и. к.* **электропәке**. --- *бүләк сыйфатында теләсә кайсы әйберне сатып алырга була. Мәсәлән, яңа күлмәк, --- хушбуй, электрокырынгыч, савыт-саба җыелмасы һ.б.* Юлдаш

**ЭЛЕКТРО́ЛИЗ** *и. рус хим.* Эремә хәлендәге матдәне, аның аша даими электр тогы үткәреп, төрле состав өлешләргә аеру процессы. *Электродларда электр тогы ярдәмендә бара торган окисьлашу-кайтарылу реакцияләре электролиз дип атала.* Химия. *Фарадей законнарыннан, электролиз вакытында бер валентлы матдәнең бер грамматомын аерып чыгару өчен, электролит аша 965 000 кулон электр корылмалары уздырырга кирәк, дигән нәтиҗә чыга.* Физика курсы

**ЭЛЕКТРОЛИ́НИЯ** *и. рус* Тимерчыбык, кабель, багана һ.б.ш.дан торган электр энергиясе тапшыру җайланмасы. *Әнә алда, зур адымнар ясагандай итеп, көмеш-ак төстәге югары вольтлы электролинияләрнең челтәрле мачталары тезелеп киткәннәр.* М.Хәсәнов. *Үткән ел табигать көйсезлегеннән зыян күргән электролинияләрне сафка бастыруга бик күп көч һәм ресурслар сарыф ителде.* Авыл таңнары

**ЭЛЕКТРОЛИТ** *и. рус физ.* Даими электр тогы үткәргәндә состав өлешләргә аерылырга сәләтле теләсә нинди эремә яки каты матдә. *«Теплоконтроль» берләшмәсендә махсус нейтральләштерү цехы бар юкса. Тотылган электролит шуның аша узарга тиеш.* Р.Мостафин. *Кислоталар, селтеләр һәм тозлар эремәдә электр тогын яхшы уздырганга, аларны электролитлар дип атыйлар.* Химия

**ЭЛЕКТРОЛИ́ТИК** *с.* 1) Электролитка, электролизга бәйләнешле булган. *Ярымүткәргечле турайткычлар --- аккумуляторларны кору, электролитик ванналарга даими ток бирү өчен һәм башка урыннарда кулланыла.* Р.Шаһморатова. *Электролитик конденсатор*

2) Электролиз ярдәмендә алынган. *Электролитик тимер*

3) *хим.* Химик кушылмаларның сыеклык эчендә эрегәндә анион һәм катионнарга таркалуына нигезләнгән. *Электролитларның эремәләрендә һәм эретелгән хәлдә үз-үзләрен ничек тотуларын аңлата торган теория электролитик диссоциация теориясе дип атала.* Химия

**ЭЛЕКТРОМАГНЕТИЗМ** *и. рус физ.* Электромагнит кыры белән җисемнең электр һәм магнит үзлекләре арасындагы өзлексез элемтәдән хасил булган магнит күренешләре. *Фән тарихчылары фикеренчә, профессор Абдуссәлам, электромагнетизм һәм төш кисәкчәләренең үзара көчсез бәйләнешләре хакындагы бердәм теория тудыручы буларак, А.Эйнштейн, Э.Резерфорд һәм Н.Бор белән бер рәткә куелырга лаек.* Ватаным Татарстан

**ЭЛЕКТРОМАГНИТ** *и. рус* Электр тогы ярдәмендә магнит кыры тудыру өчен хезмәт иткән, ферромагнитлы кендек һәм тимерчыбык чорнавыннан гыйбарәт булган җайланма. *Эшләгән вакытта кеше кулы белән яктылык нурын каплап алса, фотокаршылык электромагнитка ток җибәрә, һәм пресс шунда ук туктый.* Р.Шаһморатова. *Зур күтәрү көченә ия булганга күрә, электромагнитлар заводларда чуен, корыч*

*эшләнмәләр һәм аларның йомычкаларын күчерүдә файдаланыла.* Физика

**ЭЛЕКТРОМАГНИ́ТИК** *с. физ.* Электромагнетизмга бәйләнешле булган. *Электромагнитик тирбәнүләрнең кәкре сызыкларын күзәтү һәм фоторәсемнәрен алу өчен файдаланыла торган --- көпшә --- осциллограф дип аталган приборның төп өлешен алып тора.* А.Пёрышкин. *--- Попов радионы элетромагнитик дулкыннар теориясен өйрәнү нәтиҗәсендә ачты ---.* Р.Шаһморатова

**ЭЛЕКТРОМАГНИТЛЫ** *с.* Электромагнитизм белән бәйле; электромагниты булган. *Элетромагнитлы дулкыннарның билгеле диапозонда тибрәлешеннән яктылык хасил була.* Ә.Баян. *Штамплау прессларында --- электромагнитлы релега тоташкан яктылык төшеп тора.* Р.Шаһморатова

**ЭЛЕКТРОМЕТАЛЛУРГИ́Я** *и. рус* Металлургиянең электр энергиясе ярдәмендә төрле рудалардан металлар һәм эретмәләр җитештерү яки чистарту (рафинадлау) тармагы. *Чиләбе шәһәренә килеп, электрометаллургия комбинатына эшкә урнаша, курсларга йөреп, кранчы һөнәре ала, кранчы булып эшли.* Г.Мөхәммәтшин. *Сугыштан соңгы елларда электрометаллургиядә дистәләгән төрдәге мичләр барлыкка килгән.* С.Гәрәева

**ЭЛЕКТРО́МЕТР** *и. рус физ.* Электр көчәнешен, потенциалын үлчи торган җайланма. *Потенциаллар аермасын электрометр белән үлчиләр.* А.Пёрышкин

**ЭЛЕКТРОМЕ́ТРИЯ** *и. рус физ.* 1) Электрик үлчәү алымнары һәм ысуллары

2) *махс.* Җирнең электр һәм электромагнит күренешләренә нигезләнеп файдалы казылмалар эзләү ысулы

**ЭЛЕКТРОМЕХА́НИК** I *и. рус* Электромеханика белгече. *Уртада «Джордано Бруно»ның капитаны Карл Бригас. Аның янында өлкән механик Черногорский, --- электромеханик Дробышев, икенче механик Русаков.* М.Юныс. *--- курс һәм түгәрәкләр ел саен --- уннарча мең машина һәм мотоцикл йөртүче, электрик һәм электромеханик --- һ.б. белгечләр хәзерләделәр.* Г.Шакиров

**ЭЛЕКТРОМЕХА́НИК** II *с.* Нәрсәгә дә булса электр белән механик йогынты ясауга нигезләнгән. *Кафедрадагы баланска китерү җайланмасы ачык каеш күчергечле электромеханик привод белән эшләгәнгә, бу эш куркынычсызлык кагыйдәләре белән таныш булган студентларга гына рөхсәт ителә.* Машиналар һәм механизмнар теориясе. *Вибраторлар электромеханик, электромагнитик һәм пневматик төрләргә бүленә.* Төзү материаллары

**ЭЛЕКТРОМЕХА́НИКА** *и. рус* Электротехниканың электр энергиясе ярдәмендә хәрәкәткә килә торган двигательләр, машиналар, механизмнар белән эшләүгә һәм аларны эксплуатацияләүгә караган тармагы. *Максудов электромеханика цехында эшли.* Р.Ишморат. *Сугыштан соң кабат Коми АССРга килә һәм Водный посёлогында төпләнә, шушындагы электромеханика заводында эшли.* Р.Зарипов

**ЭЛЕКТРОМЕХАНИКЛЫК** *и.* Электомеханик вазифасы, һөнәре. *Нариманны училищега урнаштырып, шунда я вагоннар ремонтлаучы слесарьлыкка яки электромеханиклыкка укытып чыгарачагына ант итә-итә ышандырды.* Р.Мирхәйдәров

**ЭЛЕКТРОМИОГРА́ММА** *и. рус мед.* Мускуллар ярсынуның биоэлектрик потенциаллары графигы

**ЭЛЕКТРОМИОГРА́ФИЯ** *и. рус мед.* Мускулларда ярсыну вакытында барлыкка килгән биоэлектрик потенциалларны өйрәнү ысулы

**ЭЛЕКТРОМОБИЛЬ** *и. рус* Аккумулятордан электр энергиясе алган бер яки берничә электр двигателе ярдәмендә хәрәкәт итә торган автомобиль. *Биредәге авторемонт заводында электромобильнең үрнәк нөсхәләре ясалуы республика белгечләренең нинди исәптә торуын яхшы сөйли.* И.Низамов. *Электромобильләр эчке янулы двигательләрдән күбрәк булыр, АЗСларны миниэлектростанцияләр алмаштырыр.* Юлдаш

**ЭЛЕКТРОМОНТАЖ** *и. рус тех.* Электр җиһазларын, җайланмаларын монтажлау эше. *Горький электромонтаж җиһазлары заводы үзләренә бирелгән җаваплы заказны вакытыннан элек башкарды.* Казан утлары

**ЭЛЕКТРОМОНТАЖЧЫ** *и.* Электромонтаж белгече. *--- электромонтажчы егетләр пистолет белән аттырдылар ---.* Р.Кәрами. *Армиядән кайткач, биш ел электромонтажчы булып эшләгән --- егет иде.* Г.Тавлин

**ЭЛЕКТРОМОНТЁР** *и. рус* Электр җайланмаларын урнаштыру һәм аларны ремонтлау эшләрен башкаручы эшче. *Идарәдә Фёдор абзый, электромонтёр Рамай, мин исемнәрен белмәгән тагын бер-ике егет утыра иде.* Б.Камалов. *Тоннельгә яктылык кертүдә фидакяр эшләгәне өчен, 2 нче взводтан электромонтёр рядовой М.Сидоровка туган ягына кыска сроклы отпуск игълан ителде.* С.Шәрипов

**ЭЛЕКТРОМОТОР** *и. рус к.* **электродвигатель**. *Каяндыр --- Глуховның: – Игътибар, башлыйбыз! – дигәне ишетелде. Нәни генә электромотор гүләргә тотынды.* Җ.Рәхимов. *Әхәтов хәрәкәтсез торган генератор янында: – Ул чакны безнең колхозда гына да утызлап электромотор эшли иде, – диде.* Э.Касыймов

**ЭЛЕКТРОН** I *и. гр. физ.* Атомның состав өлеше, табигатьтә иң кечкенә масса һәм иң аз электр корылмасына ия булган, тискәре корылган, физикада ачылган беренче элементар кисәкчек. *Хлор атомы артык электрон алу сәбәпле – тискәре корылган ионга, ә натрий атомы, бер электронын югалту сәбәпле, уңай корылган ионга әверелә.* Р.Шаһморатова. *--- атом төзелеше түбәндәгедән гыйбарәт: атомның уртасында протоннар һәм нейтроннардан торган төш урнашкан, ә төш тирәсендә электроннар хәрәкәт итә.* Физика

**ЭЛЕКТРОН** II *с.* 1) Электронга (I) хас үзлекләрне куллануга нигезләнгән. *Электрон хәтер барлык сыйфатлары буенча --- кеше хәтереннән чагыштыргысыз нәтиҗәлерәк.* Кызыклы психология. *--- соңгы вакытта электрон информация җайланмалары да йогынтылы көчкә әверелә бара.* Сөембикә

2) *информ.* Электроника ярдәмендә Интернет челтәре аркылы аралашу, хәбәрләшү технологиясе һәм хезмәте белән бәйле. *Шулай да, компьютерым артына утырып, электрон почтаны карап алырга булдым.* Г.Гыйльманов. *Электрон хат. Электрон адрес. Электрон почта тартмасы*

**ЭЛЕКТРОН** III *и. гр.* **1.** Югары ныклык һәм сыгылмалылык үзлекләренә ия булган, очу аппаратлары ясауда кулланылган, алюминий һәм магнийдан торган (сирәгрәк цинк һәм марганец та булырга мөмкин) эретмә

**2.** *с. мәгъ.* Шул эретмәдән эшләнгән

**ЭЛЕКТРО́НИК** *с. ялг. к.* **электрон**. Электрон (I) үзлекләрен куллануга нигезләнгән, электрон үзлекләрен куллану белән бәйле. *Шулай да, электроник микроскоп ярдәмендә эрерәк молекулаларны күрергә һәм фоторәсемгә төшереп алырга мөмкин булды.* Физика. *Японнар бөтен дөньяны арзан*

*бәяле электроник товарлар белән тутырдылар.* Юлдаш

**ЭЛЕКТРО́НИКА** *и. рус* 1) Физиканың электроннарның электромагнит кырлар белән тәэсир итешүен һәм электрон прибор һәм җайланмалар тудыру методларын өйрәнә торган тармагы. *Очышлар белән бер үк вакытта ул электроника буенча гыйльми тикшеренүләр белән шөгыльләнә иде.* Р.Ибраһимов. *Техник электроника. Физик электроника*

2) Техниканың электрон җайланмаларны эшләп чыгару һәм куллану эшләре белән шөгыльләнә торган тармагы. *Музыка яңа тавышларга электроника ярдәмендә ия булды.* Ә.Баян. *Һиндстанда кара һәм төсле металлургия, энергетика, нефть химиясе, электроника, суднолар төзү буенча зур мөмкинлекләр ачылды ---.* М.Мәһдиев

3) *җый. и.* Электрон приборлар. *Мине сокландырганы – сәхнә техникасы. Җиһазларның, күренешләрнең тавышсыз, тиз алмашынуы – барысы да электроникага корылган.* Р.Батулла

**ЭЛЕКТРО́НЛЫ** *с.* 1) Электроны булган. *Бер электронлы атом*

2) *ялг. к.* **электрон**. *Хисамов электронлы фрезер станогында катлаулы детальләрне кыра алучы берданбер оста иде.* Х.Камалов. *Аптырагач, электронлы хисаплау машинасын эшкә җигәргә туры килде.* Г.Афзал

**ЭЛЕКТРОНОГРА́ММА** *и. рус махс.* Объектның электроннарны тарату нәтиҗәсендә күзәтелгән дифракция сурәте

**ЭЛЕКТРО́НЧЫ** *и.* Электроника, электрон җайланмалар белгече. *Хәзер менә компьютерчылар, электрончылар да бар инде. Ул чагында энергетика санаулы һөнәр исәпләнелә иде.* Мирас. *Эштән тормыш иптәше Александр Бабаевич (ул – электрончы) каршы ала, Мәскәүдә укыган кызы Мария шалтыратып хәлен белә.* Туган як

**ЭЛЕКТРОО́ПТИКА** *и. рус* Физикада матдәләрнең оптик үзлекләренә электр кыры йогынтысын өйрәнә торган тармак

**ЭЛЕКТРОПӘКЕ** *и.* Электр челтәреннән эшли торган пәке, электрокырынгыч, электр бритвасы. *«Харьков» электропәкесе күңелле генә жуылдый: ике түгәрәк пәке, әле колак янына менеп, әле ияк очына кунып, куерып шыткан кара төкләрне җыештыралар, битне иркәлиләр.* А.Гыйләҗев

**ЭЛЕКТРОПЛИТӘ** *и.* Аш әзерләү яки җылыту өчен кучерелмәле электр приборы. *Хәрабәләр арасында электроплитәнең янып бетмәгән ташы һәм стенадагы розетка эченә тыгылган вилка тимерләре күренеп тора иде.* Ф.Яруллин

**ЭЛЕКТРОПОЕ́ЗД** *и. рус* Электр көче белән хәрәкәткә китерелә торган поезд; электр поезды. *Быковога баручы электропоезд кузгала башлагач, Баграт: – Кайтышлый да тукта! – дип кычкырды.* М.Юныс. *Һәйкәл ---, ишкәкле каекта талгын Идел буйлап --- ил гизүчеләрне һәм тизгер электропоезд юлаучыларын да ерактан ук сәламли.* А.Тимергалин

**ЭЛЕКТРОПРОМЫ́ШЛЕННОСТЬ** *и. рус* Машина төзү сәнәгатенең электр машиналары, җайланмалары эшләп чыгара торган тармагы. *Университетны тәмамлавы турында диплом алгач, СССР электропромышленносте халык комиссарлары советы соравы буенча шунда эшкә калдырыла.* Шәһри Казан

**ЭЛЕКТРОПУНКТУ́РА** *и. рус мед.* Нечкә электрод ярдәмендә организмның актив нокталарына электр тогы белән тәэсир итүгә нигезләнгән рефлексотерапия ысулы

**ЭЛЕКТРОПЫЧКЫ** *и.* Электр челтәреннән эшли торган пычкы. *Әллә кайларга ишетелерлек булып ачы тавыш белән выжылдаган электропычкылар тынды.* М.Хәсәнов

**ЭЛЕКТРОРАЗВЕ́ДКА** *и. рус геол.* Электрометрия ысулы ярдәмендә файдалы казылмаларның урынын эзләү эше

**ЭЛЕКТРОСВА́РКА** *и. рус тех.* Металларны электр тогы ярдәмендә эретеп ялгау, эретеп ябыштыру. *Кая карама – утлар, утлар… Тегендә дә, монда да электросварка ялкыны җенләнә.* Э.Касыймов. *Арткы стенка, түп һәм башка детальләр ян якка электросварка ярдәмендә ябыштырылалар.* Фән һәм тел

**ЭЛЕКТРОСВА́РЩИК** *и. рус* Электросварка белгече; металларны электр тогы белән эретеп ябыштыру эшләрен башкаручы эшче. *Балка үз урынына төшеп утыруга, электросварщиклар, башларына кара пыялалы битлек киеп, тирә-якка ут очкыннарын чәчрәтеп, балканы беркетеп тә куялар.* Р.Кәрами. *Теңкәгә тигән эре тимер әрҗәләрне ике электросварщик монтажлаганда ук корып бара ала икән бит.* Х.Мөхәммәтшин

**ЭЛЕКТРОСИСТЕ́МА** *и. рус* Электростанцияләр, электр челтәрләре, электр җайланмалары һәм электр энергиясен кулланучылар барлыкка китергән тулы система. *Урта Идел электросистемасы*

**ЭЛЕКТРОСКОП** *и. рус физ.* Электр корылмалары барлыгын күрсәтә һәм үлчи торган прибор. *Электроскоп – электрланган әйберләрнең үзара тәэсир итешүләре күренешенә нигезләнеп эшләнгән прибор ---.* А.Пёрышкин

**ЭЛЕКТРОСТА́НЦИЯ** *и. рус* Энергиянең башка төрләреннән электр энергиясе җитештерә торган предприятие; электр станциясе. *Электростанцияләрдә энергия чыганагы булып саналган ягулык, агым су һәм искән җил энергияләре – Кояш энергиясенең бер төре.* Р.Шаһморатова. *Электростанция салу өчен урын сайлаганда, мәсьәләне Урта Кабанның суы саф кына түгел, йомшак та булуы хәл итә.* Р.Мостафин. *Җылылык электростанциясе. Атом электростанциясе*

**ЭЛЕКТРОСТА́ТИК** *с.* 1) Электростатика күренешенә нигезләнгән, шуның белән бәйле. *Ләкин аның кулындагы элмәк вертолёт ыргагына якынлашу белән, Юрийны электростатик көч җиргә лып итеп утыртты.* Казан утлары

2) *физ.* Корылган әйберне үткәргечкә якын китергәндә, үткәргеч өслегендә электр корылмалары килеп чыга торган. *Электростатик индукция*

3) *физ.* Хәрәкәтсез электр корылмалары хасил итә торган. *Электростатик кырны киметүнең гади генә башка бер ысулы бар: бүлмәдәге дымлылыкны күтәрергә кирәк.* Юлдаш

4) *физ.* Электр зурлыкларын үлчәгәндә, үлчәү берәмлеге итеп электростатик корылма берәмлеге алынган (СГСЭ дип тамгалыйлар). *Электростатик система*

**ЭЛЕКТРОСТА́ТИКА** *и. рус* Электродинамикада стационар халәттәге электр корылмаларының үзенчәлекләрен өйрәнә торган бүлек. *XIX гасырда --- электростатика, электромагнетизм фәннәренә нигез салына, термодинамикада һәм оптикада зур уңышларга ирешелә.* Физика

**ЭЛЕКТРОТЕРАПИ́Я** *и. рус мед.* Электр тогыннан, электр һәм магнит кырларыннан файдаланып дәвалау ысулы

**ЭЛЕКТРОТЕ́РМИК** *с.* Электр энергиясенең җылылык энергиясенә әверелүенә бәйле булган. *Корычның кайтарганда уалучанлыгы һәм искерүе электротермик ысул белән алдан көчәнеш куелган арматурлы тимербетон конструкцияләр җитештергәндә очрый.* Төзү материаллары

**ЭЛЕКТРОТЕРМИ́Я** *и. рус* Техниканың сәнәгать максатларында (мәс., электр мичләрендә металл эретүдә, эретеп ябыштыру процессында) электр энергиясен җылылык энергиясенә әверелдерү белән шөгыльләнә торган тармагы

**ЭЛЕКТРОТЕ́ХНИК** I *и. рус* Электр техникасы белгече. *Мартынов – электротехник.* Т.Гыйззәт. *Җәмгысе сигез төп белгечлек буенча укыталар: ветеринар, агроном, --- электротехник.* Мәдәни җомга

**ЭЛЕКТРОТЕ́ХНИК** II *с.* Электротехниканы өйрәнү һәм шуннан файдалану белән бәйле. *Бездә йөк автомобильләре, --- электротехник приборлар, медицина җиһазлары һәм кораллары, сәгатьләр һәм башка бик күп нәрсәләр җитештерелә.* Казан утлары. *Аларда неорганик кушылмаларның төп классларына караган терминнар, --- органик кушылмалар атамалары, физик һәм электротехник төшенчәләр, гальванотехник приборлар һәм җиһазлар исемлеге һ.б. тупланган.* Фән һәм тел

**ЭЛЕКТРОТЕ́ХНИКА** *и. рус* Фән һәм техниканың электр энергиясен сәнәгатьтә, авыл хуҗалыгында, көнкүрештә куллануны өйрәнә һәм тәэмин итә торган тармагы. *Конов электротехниканы да бу фән буенча махсус уку йорты бетергән кешедән ким белми.* Р.Кәрами. *[Япониядә] гидростанцияләр төзү электротехника промышленностеның үсүен – турбиналар, --- электр лампалары җитештерүне китереп чыгарды.* География

**ЭЛЕКТРОТРА́ВМА** *и. рус мед.* Электр тогы тәэсиренә эләгүдән алынган җәрәхәт, пешү һ.б.ш. --- *әгәр зыян күргән кешене электр тогы белән --- җәзалыйлар икән, --- зарарланган участокларның биопсиясе белән бәйле тикшерүләр, электротравма булган, дип инандырырга мөмкинлек бирә.* Юлдаш

**ЭЛЕКТРОТРА́КТОР** *и. рус* Электр двигателе ярдәмендә хәрәкәткә китерелә торган трактор

**ЭЛЕКТРОФИЗИОЛО́ГИЯ** *и. рус* Физиологиянең тере тукымаларда электр күренешләрен, организмга электр тогы тәэсир итү механизмнарын өйрәнә торган тармагы. *Электр моторын промышленность предприятиесендә файдаланып караганнан бирле, электротехниканың үсүе электрофизиологиянең бик тыйнак казанышларын арткы планда калдыра.* Кызыклы физиология

**ЭЛЕКТРОФИЛЬТР** *и. рус* Электр ярдәмендә газларны каты һәм сыек кисәкчәләрдән арындыру җайланмасы

**ЭЛЕКТРОФОР** *и. рус* Индукция ярдәмендә электр корылмалары хасил итү өчен кулланыла торган электростатика приборы

**ЭЛЕКТРОФОРЕЗ** *и. рус физ.* 1) Суспензия яки эмульсиядәге корылган коллоид кисәкчекләренең потенциаллар аермасы тәэсирендә электродка таба хәрәкәт итүе күренеше

2) Шушы күренешкә нигезләнгән, торфны, буаларны киптерү, балчык, эремәләр составын өйрәнү, медицинада дәвалау кебек максатларда кулланылган ысул; шуның җиһазы. *Бер дигән УВЧ, электрофорез, ЭКГ дигән аппаратларын урлаттылар.* З.Дәүләтов. *Югары катта физиотерапия бүлмәләре тезелеп киткән: электрофорез, гальваник яка, кварц, УВЧ, Бернард тогы, амплиплюс аппараты, ультратавыш белән дәвалау җайланмалары.* Казан утлары

**ЭЛЕКТРОХИ́МИК** *с.* 1) Электрохимиягә мөнәсәбәтле булган. *Фарадейның икенче законы матдәнең электрохимик эквиваленты белән атом авырлыгы һәм валентлыгы арасындагы бәйлелекне билгели.* А.Пёрышкин. *--- предприятиедән аккан суда --- агулы цинк кушылмалар бар иде. Моның өчен электрохимик заводның баш инженеры Р.Гыйльфановка --- штраф салынды.* Р.Мостафин. *Электрохимик эквивалент*

2) *хим.* Металлга электр үткәрүчән тирәлекнең тәэсир итүе нәтиҗәсендә барлыкка килә торган. *Электрохимик коррозия*

**ЭЛЕКТРОХИ́МИЯ** *и. рус* Физик химиянең электр тогы ярдәмендә барлыкка китерелгән химик процессларны һәм химик процесслар нәтиҗәсендә тудырылган электр күренешләрен өйрәнә торган тармагы. *Атаклы рус физигы Василий Владимирович Петров хәзерге заман электрохимиясенең нигезен ачкан.* СССР тарихы. *Электр тогына ия булу башка табигать фәннәренә дә тәэсир итә, аерым алганда, химик элементларның төзелеше турындагы белемнәрне киңәйткән электрохимия үсешкә ирешә.* Бөтендөнья тарихы

**ЭЛЕКТРОЦЕХ** *и. рус* Электр энергиясе җитештерә яки электр белән тәэмин итеп тора торган цех. *Электроцехтан Айдаров дигән берәү, дүртенче участоктан электрны өзеп торабыз, бетон бирүне туктатып торыгыз, дип хәбәр иткән.* А.Гыйләҗев

**ЭЛЕКТРОШОК** *и. рус* 1) *мед.* Кайбер психик авыруларны баш миенә электр импульслары белән тәэсир итеп дәвалау ысулы. *Ир чынлап та суламый иде. --- Кулдан килгәннең барысын да эшләделәр. Тик ясалма сулыш алдыру да, электрошок та ярдәм итмәде.* Г.Әдһәм

2) *к.* **электрошокер**. *Салым полициясе --- билләренә электрошок тагып, козырёклы фуражкалардан һәм аерым формадан йөрми.* Казан утлары. *Электрошок кешене аяктан егарга да, шулай ук вакытлыча «катырып» калдырып, бер адым атламаслык итәргә дә мөмкин.* Юлдаш

3) Электр тогы белән зарарланудан барлыкка килә торган шок

**ЭЛЕКТРОШО́КЕР** *и. рус* Кешене яки хайванны югары көчәнешле электр тогы белән вакытлыча хәрәкәтсезләндерергә сәләтле, гадәттә үзеңне саклау чарасы буларак кулланыла торган компакт җайланма; шокер. *Россиядә 1996 елда кабул ителгән ГОСТ буенча, электрошокерлар өч төркемгә бүленә: 50–60 киловольт, 35–50 киловольт һәм 35 киловольттан кимрәк.* Файдалы киңәшләр

**ЭЛЕКТРОЭНЕРГЕ́ТИКА** *и. рус* Энергетиканың электр энергиясен рациональ җитештерү һәм бүлү нигезендә халык хуҗалыгын электр белән тәэмин итү тармагы. *Һөнәрләре буенча эшкә урнашканда, шулай ук атом-төш энергетикасы, шәфкать туташы, фармацевтика, электроэнергетика һәм химия технологияләре белгечлеге дипломнары ияләре дә бернинди дә авырлык кичермиләр икән.* Татарстан яшьләре

**ЭЛЕКТРОЭНЕ́РГИЯ** *и. рус* Электростанцияләрнең электр челтәрләренә биргән яки кулланучы электр челтәреннән алган энергия. *Көймәнең электроэнергиясе бетеп бара, аккумулятор батареялары күптән инде соңгы көчләрен бирәләр.* Г.Әпсәләмов. *Мине бала чактан --- киләчәккә өметләнеп яшәргә өйрәттеләр. Биш елдан – кеше башына фәлән кило ит, фәлән тонна чуен, фәлән киловатт электроэнергия.* М.Юныс

**ЭЛЕКТРОЭНЦЕФАЛОГРА́ММА** *и. рус мед.* Баш мие эшчәнлегенең биоэлектрик потенциалларының график язмасы. --- *йокыдагы кешене электроэнцефалограммалар ярдәмендә физиологик тикшерүләр бу мәсьәләнең шактый катлаулы икәнен күрсәттеләр.* Кызыклы психология

**ЭЛЕКТРОЭПИЛЯ́ЦИЯ** *и. рус мед.* Югары ешлыктагы электр тогы белән тәэсир итеп, тәндәге чәчләрне, төкләрне бетерү процедурасы. *Кояш һәм ультрашәмәхә нурларның активлыгы аркасында, матурлык салоннарында ясала торган пилинг, битне агарту һәм электроэпиляция процедуралары тыела.* Кәеф ничек?

**ЭЛЕ́КТР ТОГЫ** *и. физ. к.* **электр** (*1, 2 мәгъ.*). --- *үз чиратында турбина генератор дигән машинаны әйләндерә башлый. Генераторда без электр тогы хасил булганын күрәбез.* А.Алиш. *Электр тогы булмагач, кибет һәм киосклар, даруханә һәм кафелар да ябылды, аптыраган халык урамга чыкты.* А.Тимергалин

◊ **Электр тогы кагылгандагы кебек** Сискәнеп, бер мизгелгә ирексездән кинәт калтырап яки катып калып. *Кысык күзле, тар маңгайлы кешенең тәне ялгыш электр тогына кагылгандагы кебек калтыранып куйды.* Г.Гобәй. **Электр тогы куыргандай** *к.* **электр тогы кагылгандагы кебек**. *Купцов Сорокинның йөрүеннән туктаганын, электр тогы куыргандай кинәт тартышып куйганын шәйләде: – Әйе, бер бик яхшы иптәшебезне коткарганда суга батып үлде.* Т.Мөбарәков. **Электр тогы узгандай** *к.* **электр тогы кагылгандагы кебек**. *– Завуч!.. – дигән бер генә сүз кычкырды да класска кереп юк булды ---. Коридор буйлап электр тогы узгандай булды, һәм --- тузан болыты эченнән ялтыравыклы күзлек пыялалары күренде.* М.Мәһдиев. **Электр тогы суккандай** *к.* **электр тогы кагылгандагы кебек**. *Аның шул бер сүзе, электр тогы суккандай, һәммә кешене тетрәнергә мәҗбүр итте.* Р.Гайфуллина. *Алкин, хәбәрне әйтеп бетерер-бетермәс, идәнгә утырды. Электр тогы суккандай катып калдык.* Л.Гыйззәтуллина

**ЭЛЕ́КТРУМ** *и. гр.* Табигый алтын белән көмеш катнашмасы, минерал. *Югарыда әйтеп үтелгәнчә, антик чорда акча сугуда алтын һәм көмеш катнашмасы – электрум, көмеш һәм бакыр катнашмасы – билон, алтын һәм көмеш файдаланылган.* Ә.Мөхәммәдиев. *Тәңкәләр табигый алтын һәм көмеш катнашмасы – аксыл сары төстәге электрумнан сугылган.* Сөембикә

**ЭЛЕКТРҮТКӘРҮЧӘН** *с.* Электр тогы үткәрүгә сәләтле

**ЭЛЕКТРҮТКӘРҮЧӘНЛЕК** *и. физ.* Нинди дә булса матдәнең, материалның электр тогы үткәрүгә сәләтлелеге. *Металларның электрүткәрүчәнлеге чагыштырма каршылык дигән физик зурлык белән характерлана.* Р.Шаһморатова. *Кристалл челтәренең дефектлары кристалларның ныклылык, электрүткәрүчәнлек, яктылыкны йоту --- һ.б. үзлекләренә зур йогынты ясый ---.* Физика

**ЭЛЕ́КТРЧЫ** *и. сөйл. к.* **электромонтёр**. *Электрчылар җитмиме? --- Шунда ук штаб члennарының берсенә шәһәр предприятиеләреннән тиешле санда белгечләрне табу йөкләнә.* Р.Мостафин. *Әти комбайнчы да әле ул, тимерче, электрчы да.* Г.Мөхәммәтшин

**ЭЛЕ́К-ЭЛЕКТӘН** *рәв.* Электән үк, күптәннән бирле, борын-борыннан. *Элек-электән кырыс Зөһрә әтисе үлгәч бөтенләй чыгырыннан чыкты.* Ә.Фәйзи. *Сәйфи ягымлы сүзнең көчен, юмалап әйткән мактау сүзенең таштай каты йөрәкләрне дә үзенең татлы ширбәте белән эретеп җибәрүен электән яхшы белә иде.* Г.Әпсәләмов. *Безнең милләт элек-электән бөтен Рәсәйдә иң белемле-укымышлы халыктан саналып килде.* М.Хәсәнов

**ЭЛЕМЕНТ** *и. лат.* 1) Борынгы рим философиясендә табигать күренешләренең һәм барлык әйберләрнең нигезендә ята торган төп дүрт өлештән һәрберсе (су, ут, һава һәм җир)

2) *кит.* Нәрсәнең дә булса яралгысы, беренчел берәмлекләре, башлангычы. *Колбиләүчелек җәмгыяте эчендә җитештерүнең яңа – феодаль ысул элементлары туган.* Политэкономия

3) *кит.* Нәрсәнең дә булса иң гади нигезе, башлангыч мәгълүматлары, төп кагыйдәләре. *Югары математика элементлары*

4) *хим.* Тагы да гадирәк состав өлешләргә бүленми, ирекле хәлдә гади матдә булып санала торган химик матдә. *Дмитрий Иванович Менделеев гомере буена элементларның периодик системасын камилләштерү өстендә эшләде.* В.Курбатов. *Лаклания элементы ярдәмендә электр тогы алуга ирештек.* Г.Ахунов

5) Бербөтен нәрсәнең состав өлеше, нәрсәнедер тәшкил иткән кисәкләрнең берсе; гонсыр. *Үзенең җырларын җырлап уйнаганда, әнкәй фортепьяно партиясенә көтелмәгән гаҗәеп импровизация элементлары кертеп башкара.* Ә.Айдарская. *Төрле геометрик конфигурациядәге яка һәм кесә кебек элементлар да – быелгы җәйгә хас яңалык.* Сөембикә

6) Катлаулы әйбернең характерлы үзенчәлеген яки төп нигезен тәшкил иткән бер билге, бер сыйфат. *Драма булуга карамастан, Г.Камалның башка әсәрләрендәге кебек, «Уйнаш»та да комедия элементлары шактый күп кертелгән.* М.Галәү. *Әсәрләрнең теле, гомумән стилистика элементларына килсәк, аларның да шул әсәрләрнең гомуми стиленә багланганын, шуңар тапкыр рәвештә бирелгәнен күрәбез.* Г.Нигъмәти

7) Нинди дә булса җәмгыятьнең, иҗтимагый катлауның вәкиле. *Ул – бөтенләй башка кеше, башка шартларга куелган, җәмгыять читләштергән элемент.* А.Гыйләҗев. *Өязгә караган авылларда контр элементлар кыбырсый башлавы турында соңгы көннәрдә хәбәрләр ишетелә башлаган иде.* В.Нуруллин

8) *сөйл.* Нинди дә булса шәхси һ.б. үзенчәлеге белән аерылып торган кеше, шәхес. *Сена күпере асларында Парижның бөтен кызганыч типлары күзгә ташлана: картаеп урамга ташланган фахишәләр, ач калган картлар, --- шунда ук җитмеш җиде төрле венерик авыруы белән азап чигүче кызганыч элементлар.* Г.Гобәй. *Председатель, яшелчә бригадиры итеп нинди аңсыз элементны тотасыз сез анда?* Б.Камалов

9) Химик процесслар хисабына электр тогы барлыкка китерә торган әсбап; электр батареясе. *Коры элементлар*

**ЭЛЕМЕНТАР** *с. лат.* 1) Нәрсәнең дә булса нигезенә генә кагылышлы, төп нигезне генә эченә алган; башлангыч, иң гади. *Минем шушы уен аркылы элементар геометрия кагыйдәләрен балаларга аңлату – авторның максаты, һәм ул үз максатына ирешкән.* Р.Батулла. *--- күп гасырлар, меңьеллыклар дәвамында кешелек башта – элементар, соңрак җитдирәк, катлаулырак ачышлар ясый башлаган.* К.Гыйззәтов

2) Минималь, төп, нигез, иң мөһим, иң кирәкле. *Казанның матди хәле бик авыр, иң элементар әйберләр – булка, сөт кебек ризыклар кысылган, сөткә чиратны иртә таңнан аласы, сәгатьләр буе чират торасы иде.* М.Мәһдиев. *Яшәү өчен кирәкле иң элементар әйберләр: синең сәнгатьтәге уңышың, абруйлы эшең, атказанган кешеләр белән аралашу.* И.Юзеев

3) *хим.* Нәрсәдә дә булса элементларның составын һәм аларның үзара нисбәтен ачыклауга бәйле булган. *Эле-*

*ментар ячейка. Матдәнең элементар составы*

4) *физ.* Билгеле булганнарның иң кечкенәсе, иң гадие. *Башта электрның атом структуралы булуы, ягъни аның тигез өлешләргә – элементар электр корылмаларына бүленә алуы билгеле булды.* А.Пёрышкин. *XIX гасыр ахырында тискәре электр йөртүче элементар кисәкчек – электрон ачыла.* Физика

5) *күч.* Гади, катлаулы булмаган; гадәти. *Ләкин авырулар врач белән «сез» дип сөйләшергә тиешләр. Монысын инде элементар этика таләп итә.* Г.Рәхим. *Мавыктыргычлар шулай «уйнап кына» баланы тормыш хакыйкатенә төшендерү, элементар тормыш законнарына өйрәтү үзлегенә ияләр.* Р.Ягъфәров

6) *күч.* Үтә гади, аңлаешлы, һәркемгә аңлашыла торган, примитив. *Мин әйтәм, сыйфат ул --- мондый лозунг куелмыйча да булырга тиешле зарури, элементар таләп, дим.* Г.Зәйнашева. *Исхакыйга шул гына кирәк булды, ахрысы, ул, горур, серле кыяфәт алып, наданнарга элементар нәстәләрне аңлаткан кебек дәвам итте: тарих укытучысы уңай персонаж түгелмени?* Р.Батулла

7) *күч.* Җиңелчә, өстән генә, гадиләштерелгән, чикләнгән. *Мәсьәләгә элементар караш*

**ЭЛЕМТӘ** *и.* 1) Үзара мөнәсәбәтләр; аралашу; бәйләнеш. *Алардан соң, институтта эшләмәсәләр дә, ректорга мөнәсәбәте булырга мөмкин шәхесләр, әйтик, райпо рәисе --- якындагы совхоз, колхоз хуҗалары белән элемтәләр тикшерелде.* Т.Галиуллин. *Моннан бик күп еллар элек ул, кайнанасы белән килешә алмыйча, дөнья күчереп ызгышып, имчәк баласын ташлап киткән булган икән. Шул китүдән Факиянең эзе югалган, ул яклар белән элемтә өзелгән.* М.Мәһдиев

2) Кем белән дә булса якынлык, эчке бердәмлек, үзара аралашу нигезендә туа торган бәйләнеш. *Октябрь стачкасында Россиянең төрле милләт эшчеләре арасындагы элемтәләрнең ныгуы күренде.* СССР тарихы

3) Дусларча, иптәшләрчә яки ниндидер бер эш буенча бәйләнеш, аралашу, хәбәрләшү күренеше. *– Безгә элемтәне дәвам итәргә кирәк, --- диде Бакый, янәдән шаян тонга күчте.* М.Маликова // Аралашкан кешеләр. *Гаиләм, җылы почмагым, тыныч тормышым, яшәү дәверендә барлыкка килгән элемтәләрем – барысы да түбәндә калды.* М.Юныс

4) Турыдан-туры аралашуы булмау сәбәпле, берәр кеше яки берәр нәрсә аша башка берәү белән бәйләнештә булу, хәбәрләшеп тору күренеше. *Бу хат менә шул ике арадагы элемтәне башлап җибәрү теләге белән языла. Арадагы бәйләнешне өзмичә, һаман хат язышып торсак, шәп булыр иде.* М.Җәлил. *Кеше тышкы дөнья белән «сакчы пункт» аша элемтәдә була.* Кызыклы психология

5) Ерактан торып аралашу, хәбәрләшү чарасы, ысулы, юлы; бәйләнешкә керү мөмкинлеге. *Элемтәне яңарту өчен, икенче взводка кеше җибәрәм.* И.Гази. *--- хәрби закон шундый: бер юнәлештә хәрәкәт итүче частьләр даими элемтәдә торырга тиешләр.* М.Маликова

6) Техник чаралар белән ерак аралардагы бәйләнешне тәэмин итә торган учреждениеләр, системалар (телеграф, телефон, почта, электрон почта, Интернет, радио) җыелмасы. *Ахияр ул елны элемтә бүлеге начальнигы булып эшли иде.* М.Мәһдиев. *Әгәр ул элемтә бүлегенең тимерчыбык җибәрмәве, тегесемонысы хакында турыдан-туры райком секретарена әйтсә, Ханов аның сүзләрен илтифатсыз калдырмас.* С.Рафиков

7) Радио, телефон ярдәмендә, кеше аркылы һ.б.ш. юллар белән хәрби подразделениеләрнең үзара бәйләнешен тәэмин итә торган хезмәт. *Монда синдәйләр аралаша: соры шинельле солдатлар, офицерлар, һава көчләре, десант, танк, элемтә, эчке эшләр, чик буе гаскәре малайлары.* М.Мәһдиев

8) *күч.* Танышлык, белешлек. *--- әнисенең элемтәләреннән башка да кызый медицинскийга урнашып, шунда фармакологиядә укып йөри икән.* М.Мәһдиев

**ЭЛЕМТӘЧЕ** *и.* 1) Элемтә хезмәткәре. *Ә мин шул чакта тоттым да кыска сроклы элемтәчеләр курсына язылдым.* Ә.Еники. *Элемтәчеләр ашыгып тимерчыбык суза, антенна күтәрә.* И.Гази

2) Арадашчы. *Без – Көнчыгыш белән Көнбатыш арасында буталып калган, әмма чын дәүләтчелеге булса, ике арада --- элемтәче булырга тиешле халык.* Т.Галиуллин. *– Өченче куяныбыз – Миша исемле теге малай. Тычинкинаның улы. Алар [җинаятьчеләр] аны элемтәче итеп йөртәләр булса кирәк, – диде ул.* М.Насыйбуллин

**ЭЛЕНКЕ́-САЛЫНКЫ** *рәв.* **1.** 1) Теләр-теләмәс, күңел бирмичә, көч куймый гына, тырышмыйча, өстән-өстән, аннан-моннан гына. *Әмир, өлкәннәр җитдилеге белән: – Эленке-салынкы укысаң, синә да югары уку йорты тәтемәс.* Т.Галиуллин. *Эленке-салынкы йөрүчеләр күбәйде. Халык күмәк эшкә элеккечә дәртләнеп кушылмый иде инде.* Н.Гыйматдинова

2) Билгеле бер максатсыз гына. *Эшкә килгәч тә бригада беркавым эленке-салынкы йөри, тарта, гәп суга.* А.Гыйләҗев

**2.** *с. мәгъ.* 1) Эленеп-салынып торган. *Урман, төнге йокысыннан уянып, эленке-салынкы ботаклары белән кыштырдый вә шыпырт кына сөйли башлады.* Ф.Әмирхан. *Бар маллары хатыннарының күлмәкләренә, --- әллә нинди эленке-салынкы чүпрәкләренә кереп беткәнгә күрә, ирләренең --- җәмәгать эшләренә сарыф итәргә бер тиен акчалары да булмый.* М.Гали

2) Болытлы; сүрән, явар-яумас. *Хәер, иртәсе дә караңгы чырайлы, эленке-салынкы түгел, бик ягымлы, бик тә ямьле булып, матурланып килә иде.* Г.Бәширов. *--- авылыбыз күген Ибрай абзыйның иске толыбы сыман эленке-салынкы болытлар томалаган.* Ш.Маннапов. *Көзнең эленке-салынкы көннәре*

3) Эшлексез, ялкау, максатсыз булганып йөрегән (кеше тур.). *Табигать бушлыкны --- нәрсә белән, кем белән тутырыр соң? Чүп-чар, эленке-салынкы кешеләр беләнме?* Х.Камалов

4) Хәлсез, дәртсез. *Кояшның --- эссе нурлары әллә нинди бер ару-талчыгу тойгысы биреп, кешеләрне эленке-салынкы бер хәлгә төшерәләр ---.* М.Галәү. *Нишләргә белмәүдән аптыраганнан гына Рәхим, урыныннан кузгалып, эленке-салынкы адымнар белән станциягә таба атлады.* А.Вергазов

5) Төшенке, күңелсез, басынкы. *Белә, күрә Динә: Баязитның дөньяда гаме юк, эленке-салынкы кәефенең очы Сайра белән алкаларда икәнен дә сизенә!* Н.Гыйматдинова

**ЭЛЕНКЕ-САЛЫНКЫЛАНЫП** *рәв.* Ялкауланып, теләр-теләмәс кенә, эшлисе килми генә. *Шулар гына җитмәгән, әле корсагын тагын бәбәйгә түгәрәкләндереп йөргән җиңгәсе бар. Анысы – тач кычыткан. Эленке-салынкыланып, үшәнләнеп йөрсәң, чагарга гына тора.* В.Имамов

**ЭЛЕНКЕ́-САЛЫНКЫЛЫК** *и.* Оешмаганлык, ялкаулык, көч куймый гына, өстән-өстән генә, аннан-моннан гына, теләр-теләмәс эшләү рәвеше. *Бераздан, --- капитан Фёдор Петрович сүз сорагач, Нәзифә эсселе-суыклы булып*

*китте: эштә эленке-салынкылыкны --- сөймәгән таләпчән карт елгачы, мена хәзер бөтен команда алдында тиргәп, оятлы итәр төсле тоелды.* С.Сабиров. *Һәр эштә дә, сүздә дә тәртип. Эленке-салынкылык юк.* К.Тимбикова

**ЭЛЕНМӘЛЕ** *с.* Элеп, асып куярга җайланган, элеп куела торган, эленгән. *Рәхимҗан абые каршында, эленмәле җиделе лампаның икенче ягында, хуҗабикә утыра.* М.Хәсәнов

**ЭЛЕ́Н-САЛЫН** *рәв. сир.* Бик үк әйбәт түгел, бик шәптән түгел, начар гына. *[Сәгъди белән Зөһрә] күрер күзгә элен-салын гына яшәсәләр дә, кеше күзенә карап яшәмәделәр.* Ә.Фәйзи

**ЭЛЕНҮ** *ф. төш. юн. к.* **элү**. *Дәү апаның --- салынып төшкән иңбашларына борчак-борчак бизәк төшерелгән аксыл зәңгәр күлмәк эленгән.* Р.Мөхәммәдиев. *Керфек очына эленгән яшь тамчыларын кул аркасы белән сыпырып төшерәм дә буш урам буйлап йөгерәм.* М.Галиев

**Эленеп калу** Эленгән хәлгә килү. *Җиңел генә калтыравык бөтен тәннән йөгереп узды да бармак очларында эленеп калды.* Г.Әдһәм. *Акбай, борын төбендә эленеп калган шул исне хәтерендә калдырырга теләгәндәй, озак кына һава иснәп торды.* Язмышлар яңарганда

**Эленеп тору** Озак вакыт яки даими эленгән хәлдә булу. *Каракучкылланып килгән болыт бер якка да авышырга теләмәде, нәкъ авыл өстендә эленеп торды.* Р.Мөхәммәдиев. *Түбән Кама эчке эшләр идарәсендә әлеге сигнал гаять җитди кабул ителә. Чөнки соңгы бер-ике ай эчендә генә дә шәһәрдә 10 нан артык фатир басу очрагы ачылмыйча эленеп тора.* Мәдәни җомга

**ЭЛЕ́Ң-САЛЫҢ** *рәв. сир. к.* **эленке-салынкы**. *Ашыгып эшне бозмагыз, әмма тугарылып китеп, элең-салың йөреп, озакка да сузмагыз.* Т.Әйди

**ЭЛЕРОН** *и. фр. авиа* Канатларының арткы өлешенә шарнирлар ярдәмендә беркетелеп, горизонталь очыш һәм борылу вакытында очкычны янтайтмас өчен хезмәт итә торган җайланма. *76 пассажирны утырткан очкычның канатлары элероны (канат очы белән идарә итә торган руль өслеге) җимерелгән булган.* Татарстан яшьләре

**ЭЛЕУТЕРОКОКК** *и. лат. бот.* Аралиячәләр семьялыгыннан Ерак Көнчыгышның катнаш ылыслы урманнарында үскән, тамырыннан дару ясала торган куакчыл үсемлекләр ыругы. *Аручанлыктан әнәле элеутерококк төнәтмәсе файдалы.* Сөембикә. *Биостимуляторлардан эт җиләге, женьшень, радиола, элеутерококктан әзерләнгән төнәтмәләр кулланырга киңәш ителә.* Сәламәт булыйк!

**ЭЛИ́ЗИЙ** *и. гр. миф.* Антик мифологиядә тартарга каршы куелган, җирнең көнбатыш читендә үлемсез батырларның рәхәттә яши торган урыны

**ЭЛИ́ЗИУМ** *и. гр. миф. к.* **элизий**

**ЭЛИ́ЗИЯ** *и. лат. лингв.* Сүз ахырында килгән сузыкның икенче сүзне башлаган сузык аваз алдында төшеп калуы (мәс., *кердә алмыйм* урынына *керәлмыйм*, *түлә әле* урынына *түләле*). *Компонентларның берсе чагыштырмача кыска сузык булганда да элизия күренеше була: юкмы әллә? [йукмәллә].* Татар грамматикасы. *Кушма сүзләр ясаганда барлыкка килгән элизия күренеше, гадәттә, орфографиядә дә чагылыш таба.* Ф.Сафиуллина, М.Зәкиев

**ЭЛИКСИР** *и. гар.* 1) Үзенең составында, төрле төнәтмәләрдән тыш, дару, хушисләндергеч һ.б. матдәләр булган, медицина һәм косметикада кулланыла торган сыекча. *Кибеткә тирләүгә каршы бер сум ун тиенлек бер сыеклык кайткан иде – аңа рәхәтләнде, беразлан «Зубной элексир»га күчте, аннан – көя даруына.* М.Мәһдиев

2) Урта гасыр алхимиклары күзаллавынча, мәңге яшьлек эчемлеге, тереклек суы. *Күпме хыялый яшәгән Эзләп элексир! Имеш, табылган ул, ләкин Булган элек сер!* Х.Бәдигый. *--- бүген, нәфис затны яшәртү өчен, медицина өлкәсендә дә, косметологиядә дә берсеннән-берсе яңарак ысуллар, «яшьлек элексир»лары уйлап табыла.* Юлдаш

**ЭЛИМИНА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Нәрсәне дә булса бетерү, юк итү, юкка чыгару, чыгарып ташлау

2) *мат.* Тигезләмәләр системасыннан билгесезне чыгару гамәле

3) Палеонтологиядә табигый сайланыш нәтиҗәсендә бөтен төркемнең яки аерым бер организмның һәлак булу очрагы

4) *мед.* Абиотик һәм биотик факторлар тәэсирендә организмнарның төрле матдәләрне чыгаруы күренеше

**ЭЛИТ** *с.* 1) *биол.* Элита (*1–2 мәгъ.*) булып торган, элитаны (*1–2 мәгъ.*) тәшкил иткән. *Бүген алар уҗым арышының элит сортын урып җыя.* Алга

2) Сайланма, иң югары сыйфатлы; шәп. *Фатирсыз интекте халык... Хәзер ул да җитәрлек, Элит йортлар сафка баса... Матурлар, искитәрлек!* Д.Гыйсметдин

**ЭЛИ́ТА** *и. фр.* **1.** 1) *а.х.* Аерым үсемлекләрнең яки хайваннарның селекционерлар тарафыннан яңа сортлар һәм яңа нәсел чыгару өчен сайлап алынган иң яхшы төрләре һәм токымнары

2) Культуралы үсемлекләрдән орлык җитештерүче хуҗалыклар һәм селекцион станцияләр тарафыннан чыгарылган югары сортлы орлыклар. *Шушы посёлок урнашкан басуга гәрдәләләр азаккы тапкыр борчак чәчкәннәр иде. Сортлы борчак – элита иде!* Э.Касыймов

3) Җәмгыятьнең иң күренекле вәкилләре, сайланма өлеше; югары катлау. *Ну, чын хисләр хәзер аерым бер элитага гына хас.* Ә.Баян. *Комсомол элитасында кабул ителгән шартларны үти алмасаң --- халык хуҗалыгына озатылуыңны көт тә тор.* Т.Галиуллин

**2.** *с. мәгъ.* 1) Элита (*3 мәгъ.*) булып саналган; элитар. *Алар ничектер «әдәбияттагы исем генә әдәбиятта булырга тиеш» дип уйлыйдыр кебек. Шуңа күрә хәзер элита исемнәр барлыкка килде.* Х.Сарьян

2) Элита (*1–2 мәгъ.*) булып саналган; элит. *Ул туп-туры әйтә, элита орлыклар белән һәр хуҗалык үзен үзе тәэмин итәргә тиеш, ди.* Н.Гамбәр

3) Сайланма, иң югары сыйфатлы; шәп

**ЭЛИТАЛЫ** *с.* 1) Үзенең элитасы булган. *Милли элиталы җәмгыять*

2) *ялг. к.* **элита**. *Элиталы кукуруз*

3) *ялг. к.* **элит**. *Чистай урамында элиталы биек йортта бер бүлмәле фатирыбыз бар.* Сөембикә

4) *ялг. к.* **элитар**. *Монда бөтен татарның булачак элитасы да килеп укырга (хәтта чит илләрдән дә) һәм элиталы мөгаллимнәр укытырга тиеш.* Р.Вәлиев

**ЭЛИТАР** *с.* 1) Элита (*3 мәгъ.*) өчен билгеләнгән, элитага дигән. *Элитар сәнгать ул – аерым бер катлау, бер төркем өчен генә хезмәт иткән сәнгать.* Н.Гамбәр

2) Элитаны тәшкил иткән; элитадан торган. *Мондый элитар катлам, интеллектуаль хезмәт кешесе хакында, белгәнегезчә, бездә әсәрләр аз языла.* М.Вәлиев. *Көчле милләт һәрвакыт үзенең элитар кешеләрен саклый, аларны үстерә ---.* Р.Сибат

3) Камил дәрәҗәгә җиткерелгән; нәзакәтле, нәфис, нечкә

**Э́ЛЛИН** *и. гр.* Борынгы грек. *Мәгәр эллиннарда куәт алып, көчәеп, зур*

*ташкын булып килгән христиан дине Диоклетианның да рухын сындыра ---.* М.Хәбибуллин. *Традицион табылдыклар белән бергә Алтайның Майэмир каберләрендә классик скиф һәм элгәреге эллин эпохасыныкына охшаш әйберләр табыла.* Г.Фәйзерахманов

**Э́ЛЛИНГ** *и. голл.* 1) Яр буенда судноның корпусын төзү, ремонтлау һәм саклау өчен төзелгән авыш яссы фундаментлы корылма. *Эллингларда борылырга да урын юк. Шуңа күрә кыйммәтле көймәләр дымлы подвалларда саклана.* Социалистик Татарстан

2) Дирижабльләр һәм башка оча торган аппаратларны төзү, ремонтлау һәм саклау урыны

**ЭЛЛИНИЗМ** *и. гр.* 1) Борынгы эллиннар мәдәниятенең, безнең эрага кадәр 334–324 елларда Македонияле Искәндәр яулап алганнан соң, Көнчыгышта таралган чоры. *Нәфасәт теориясен эшкәртү эллинизм чоры ---өчен дә хас була, ул ике капма-каршы юнәлештә чагыла.* К.Гыйззәтов. *Эллинизм дәверендә Мисыр календаре шушы үзенчәлеге аркасында кучмә диган исемне алган.* Фән һәм тел

2) Борынгы грек теленнән алынган сүз яки әйләнмә

**ЭЛЛИНИСТ** *и. гр.* Борынгы грек теле һәм әдәбияты белгече; шулар белән мавыккан, шуңа мөкиббән киткән кеше

**Э́ЛЛИПС** *и. гр.* 1) *мат.* Туры конусны яки цилиндрны яссылык белән кисү нәтиҗәсендә барлыкка килгән йомык кәкре сызык. *Ә планеталар? Алар ни өчен тәртипсез рәвештә хәрәкәтләнмиләр, бәлки эллипс буенча әйләнеп йөриләр?* Җ.Тәрҗеманов. *Эллипс, гипербола һәм парабола – борынгы грек галимнәре тарафыннан яхшы өйрәнелгән кәкреләр.* Югары математика нигезләре

2) Нәрсәнең дә булса шундый йомык кәкре сызыкны хәтерләтә торган контуры. *Кояш --- күлнең бер башыннан икенче башынача, сәер эллипс хасил итеп, сабыр гына йөзеп чыга ---.* К.Миңлебаев

**Э́ЛЛИПСИС** *и. гр. лингв.* Сөйләмдә үзеннән-үзе билгеле булган сүзне яки кушымчаны төшереп калдыру күренеше (мәс., *курыкканга куш күренә* диясе урынга *курыкканга – куш* дип әйтелә). *Лексик эллипсис дип, кушымчалы сүздән – кушымча, сүзтезмәдән бер сүз төшереп калдырылуны атыйлар.* Р.Әхмәтьянов. *Еш кына ул фикерне әйтеп бетерми, сөйләмне кыскарту – эллипсис алымы куллана.* В.Хаков

**ЭЛЛИПСО́ИД** *и. гр. мат.* Эллипсның үз күчәрләренең берсе тирәсендә әйләнүеннән барлыкка килгән өч үлчәмле өслек; геометрик җисем. *Көчле әйләнү аркасында эллипсоидтан томанлы бөҗра хасил булган.* А.Фәткуллин. *Күчәр тирәсендә әйләнүе аркасында, Җир шары полюслар янында кысылган һәм формасы белән әйләнмә эллипсоидны хәтерләтә.* Фән һәм тел

**Э́ЛЛИПССЫМАН** *с.* Эллипс формасындагы. *Озынча айванның яфраклары алмаш торышлы, гади, эллипссыман, --- соргылт төстә.* Урман аптекасы

**ЭЛЛИ́ПТИК** *с. гр.* 1) *мат.* Эллипс булып торган; эллипс шәкелендә булган, эллипс формасындагы. *Баллистиклар исәпләп чыгарган эллиптик орбита бар.* Галәмгә юл. *Кайбер күперләр эллиптик, гиперболик яки параболик формада эшләнәләр.* Югары математика нигезләре

2) *лингв.* Сөйләмдә үзеннән-үзе билгеле сүзне төшереп калдыруга нигезләнгән; составында эллипсис булган. *Шунысын әйтеп узарга кирәк: мондый типтагы җөмләләр аерым галимнәр тарафыннан эллиптик төзелмәләр буларак та каралалар.* Г.Нәбиуллина. *Фразеологик әйтелмәләрнең лексик составы кыскару нәтиҗәсендә эллиптик формалар яки факультатив компонентлар барлыкка килә.* Татар лексикологиясе

**ЭЛМӘ** *и. бот.* **1.** Элмәчәләр семьялыгыннан юан кәүсәле, җәенке ябалдашлы, кыйммәтле үзагачлы биек агач; карама; *русчасы*: **ильм, вяз**. *Аларны кычыткан һәм кузгалак ашы, юкә яфрагы һәм элмә кайрысы белән тамакларын туйдырып, үлемнән алып калучы да --- Айсылу үзе иде.* Г.Әпсәләмов. *Элмә – тегәрмәч тугымына, чана табанына китә, дуга бөгәргә.* М.Мәһдиев

**2.** *с. мәгъ.* Шул агачтан эшләнгән. *Атларда элмә дугалар. Элмә бөгәлҗә*

**ЭЛМӘК** *и.* 1) Бау, шнур, җеп, каеш һ.б.ш.ның очларыннан тартып кысарлык, тыгызларлык, буарлык итеп бәйләнгән өлеше. *Байтирәк, --- кәүсә әйләнәли уратып, сүс бауга элмәк ясый башлады.* М.Гомәров. *Абыйсы бауның очына элмәк ясаган. Бар көченә селтәнеп упкын аша ыргыткан да кыяга эләктергән.* Ф.Тарханова

2) Кошларны, вак җәнлекләрне аулаганда кулланыла торган, бер өлеше кысылып, тыгызланырлык итеп бәйләнгән кыл тозак. *Шулчак Яшь бүренең муенына элмәк килеп төшә дә буып ала.* Т.Миңнуллин. *--- көтүче алдан ук әзерләгән элмәкле арканын селтәп җибәрүе булган, элмәк койрыксыз бүренең муенына килеп тә эләккән.* Ф.Яруллин

3) Берәр әйберне кулга алу, тотып йөрү, куллану өчен җайлап, аңа тотка, сап урынына беркетелгән бау, каеш. *Беләзегенә киелгән каеш элмәккә ияреп, камчы артыннан Хәмзә дә атыннан егылып төште.* Т.Нәбиуллин

4) Бантлап бәйләнгән төен. *Изүләре элмәкләр белән бәйләнеп куела торган ак күлмәк өстеннән соры төстәге шыксыз халат киеп җибәргән.* М.Хәсәнов

5) Йомык яки ярымйомык кәкре формасындагы әйләнмә хәрәкәт һәм шул хәрәкәт нәтиҗәсендә хасил булган йомык яки ярымйомык сызык. *Кояш нурлары күзгә кебек шома су өстенә төшеп күзне чагылдыра, вак балыклар исә элмәк ясап сикергәли.* Н.Каштанов. *Очыш картасына күз төшереп алды ул тагы бер кат. Бу юлы шактый ук катлаулы элмәкләр ясау һәм һөҗүм тактикасын кабатларга тиеш иде ул.* Р.Мөхәммәдиев

6) *спорт* Һавада баш аша әйләнеп, элеккеге торышка кайтудан гыйбарәт булган акробатик сикерү

7) Буталчык хайван эзе (күбрәк куян эзләре тур.). *Хәйләкәр ул куян, төлкедән дә хәйләкәррәк. Юлны тиз саташтыра. Өнгә ятар алдыннан әллә нинди элмәкләр ясап бетерә.* М.Рәфыйков. *Ике бүре, элмәкләр ясый-ясый, башларын югары күтәреп пошкырып торучы буйволлар һәм сыерлар арасына килеп керделәр дә аларны икегә аердылар.* Р.Вәлиев

8) Төймәне, каптырманы эләктереп кую өчен, киемнең тышкы ягына тегеп куела торган, төймә өчен тишеге булган лентадан гыйбарәт яки бау, җеп, шнур кебекләрдән үреп ясалган тасма, нечкә тимерчыбык яки чылбыр рәвешендәге деталь. *--- әмма кызый --- сул кулы белән аркасына үрелде һәм, күз ачып йомганчы, гәүдәсен сәдәфләрдән, элмәкләрдән азат итте.* М.Мәһдиев. *Бәрәңгенең шәмәхә я ал төстәге чәчәкләре белән королеваларның камзул элмәкләрен бизәгәннәр.* Ботаника

9) Чалбарда һ.б.да билбауны аркылы үткәрү өчен тегелгән материя кисәге. *Толстовканың бөкләнеп, түгәрәкләнеп беткән чүпрәк билбавы алдан китереп эләктерелмәгән, кабырга тапкырына тегелгән ике элмәк аркылы гына үткәрелеп, артка бөкләнгән дә ике очы бергә китереп --- бәйләнгән.* М.Әмир

10) Өске киемне элеп куяр өчен, аның эчке ягына тегелгән кыска тар лента рәвешендәге элгеч. *Пинжәгемне, элмәгеннән эләктереп, егетләрчә иңбашыма салганмын.* Ә.Гаффар. *Пәлтәмнең юк кием шкафына Элеп куяр өчен элмәге.* М.Фәйзуллина

11) Берәр нәрсәне эләктереп тарту яки әйбер элеп кую өчен башы кәкре тимер яки агач корал; ыргак. *Баһадир краннар, элмәкләрен җилдә чайкый-чайкый, сәламләп каршылыйлар.* Н.Гыйматдинова. --- *урамнан кабаланып килеп кергәч, ике өй арасындагы өйалдында аркылы матчадагы элмәккә эленгән чиләкне күреп, шундагы сөтне чөмерә.* К.Миңлебаев

12) *к.* **элгеч** (*4 мәгъ.*). *Егерме дүртенче августта милиционер Даниленко белән бергә алтынчы маршрут буйлап барганда, --- Яңа шәһәрдәге икмәк кибетенең тимер элмәге йозагыние белән суырып алынганын күрдек.* М.Насыйбуллин. *Капка тимерләре алып килгәнием. Зур капкаң ачылмый бит, салынып төшкән, элмәктә генә асылынып тора.* Ф.Сафин

13) *к.* **элгеч** (*1 мәгъ.*). *Элмәккә сөлге, алъяпкыч эленгән.* Р.Фәттахова. *Өстәл өстеннән паспортын алып, ятак өстендәге элмәккә эленгән костюмының куен кесәсенә тыгып куя.* Р.Гаязетдин

14) Җептән бәйләнгән әйбердәге күз, күзәнәк. *Бәйлим әле күлмәкләр. Җеп йомгагын кием итә «Күзләр» дигән элмәкләр.* А.Юнысова. *Бишенче-алтынчы класста укыганда, кыз балалар өчен тегү-чигү түгәрәге оештырып, энә тотарга, элмәк ясарга, чигәргә дә өйрәткән класс җитәкчебез Тәнзилә апа Сиразованы онытырга мөмкинме?* Х.Гафарова

15) Буып үтерү өчен ясалган җайланма; гомумән үлем җәзасы; үлем. *Халык теле – үтәлә бу теләк... Мәлгунь Мюллер бугазында элмәк, Дар агачы аны селкетә.* Ф.Кәрим. *Моны дар агачы янына алып килгәннәр. Җәллад баудан элмәк ясагач, чегән ялварырга тотынган.* Р.Вәлиев

16) *күч.* Кемне дә булса кулга төшерү, эләктерү өчен ясалган төрле хәйләләр. *Күрде Дастан кызның «элмәк» атканын, Үзенә һәр чәче җанны тартканын.* Ә.Фирдәүси

**ЭЛМӘКЛӘ́Ү** *ф.* Элмәк ясап бәйләү. *Бауның бер очын элмәкләп, икенче очын капка түбәсе аркылы эчкә ыргыттылар.* М.Галәү. *Сүбәдәй ыштанын киде, бавын элмәкләде һәм кызның җәйрәп ятуын күреп курка калды.* М.Хәбибуллин. *Эт тартылып баруын кинәт акрынайтты – картның кулына элмәкләп киертелгән каеш бушады.* М.Хуҗин

**Элмәкләп кую** Элмәкләнгән хәлгә китерү. *Өстәл теннисы шарын кайчы очы белән тишкәннән соң, шырпы кисәгенә кара җеп бәйләп шар эченә үткәрәләр дә калган очын элмәкләп куялар.* Р.Гарифуллин. *Шуннан 1,5 метр җеп сүтеп алып, орчыкка элмәкләп куябыз.* Сөембикә

**Элмәкли башлау** Элмәкләргә тотыну. *Барсуков тимер тросны бөгеп, элмәкли башлады.* М.Юныс

**ЭЛМӘКЛЕ** *с.* Элмәге булган, элмәк ясалган. *Чүпрәк-чапрактан элмәкле бау ясап, аны түшәмдәге чөйгә элеп асылынырга йөргән Мөсәллим янында көтмәгәндә-уйламаганда пәйда була ул.* Г.Гыйльманов. *Дәфтәрдә балалар гади карандашлар белән төрле таяклар, түгәрәкләр, дугалар ясыйлар, ыргаклы һәм элмәкле туры сызыклар сызарга, шул элементларны дөрес тоташтырырга өйрәнәләр.* Сөембикә

**ЭЛМӘЛЕ** *и. сөйл. к.* **эленмәле**. --- *тинтәк сарык уттай урак өстендә элмәле күпер астына кереп бәрәнләгән.* Ф.Шәфигуллин. *Асылбикә ишек тимеренә элмәле йозак таккан иде, Хафиз ачкыч капшанып тормады, йодрыгы белән генә сугып ачты.* Н.Гыйматдинова

**ЭЛМӘЛЕК** *и.* Элмәләр үсә торган урын, элмә урманы. *Монысын кара урманда, разведкага барганда, әкрен генә җырладым: Су буйларында элмәлек, Элмәлектә йөрмәдек.* И.Юзеев. *Менә тагы шул элмәлек читендә тора Нургаяз.* Р.Мөхәммәдиев

**ЭЛМӘТАКТА** *и.* Предприятие, учреждение, оешмаларның исеме, эш сәгатьләре һ.б.ш. күрсәтелгән такта, плитә. *Ишек кырыендагы элмәтактадан егет китапханәнең эш көн-сәгатьләрен укып күңеленә сеңдерде ---.* Р.Кәрами. *Кая гына карама, латин графикасында язылган язулар: дәүләт оешмаларының элмә такталары да, кибетләрдәге инструкцияләр дә, рекламалар да...* Р.Миңнуллин

**ЭЛМӘ́-ТЕЛМӘ** *рәв.* Теткәләнеп, тотар җире калмыйча (тузу, таушалу тур.). *[Солдат] службасын тутырган, паспорты да элмә-телмә өзгәләнеп беткән.* Ш.Камал

**ЭЛМӘ́ЧӘЛӘР** *и. күпл. бот.* Икеөлешлеләр классының агачларның тугыз ыругын, башлыча тропик агачларны, берләштергән семьялыгы; *русчасы*: **вязовые, ильмовые**. *Элмәчәләр семьялыгына 18 ыруг һәм космополитик таралган 200гә якын агачсыл төр керә.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы. *Элмәчәләр поляр яны өлкәләрендә генә үсми.* Ботаника

**ЭЛОДЕ́Я** *и. гр. бот.* Субуярчалар семьялыгыннан, чыгышы белән Америкадан булган, сулыкларны чүпли, аквариумда декоратив үсемлек буларак үстерелә торган суүсем. *Элодея – су үсемлеге. Аның яфраклары вак һәм юка, ул ике катлау күзәнәктән генә тора.* Ботаника. *Кайбер үсемлекләрнең, мәсәлән, элодеяның, яфраклары буыннарда өчәрләп һәм аңардан да күбрәк булып үсәләр.* Биология

**ЭЛПӘ** *и.* 1) Тере организмнарда тышча яки пәрдә функциясен үти торган яры. *Үзенең [Су анасының] аяклары артка таба карап тора икән, элпәсе дә бар, ди.* Ф.Яхин. *Казан татарлары фольклоры лекцияләрендә бу мифологик җан иясе турында болай диелгән: «Колак анасы» турында болай дип уйлаганнар: алар әйтүенчә, колак эчендә, барабан элпәсе артында, «Колак анасы» яши, ул кайвакыт үз урыннан күчәргә мөмкин; ул вакытта кешенең колагы авырта торган була ---».* Г.Рәхим

2) *к.* **эмаль** (*6 мәгъ.*). *Теш элпәсенә зыян килмәсен өчен, гранат суын эчкәннән соң, авызны гади су белән чайкау яхшы.* Якты юл

3) Берәр нәрсәнең юка катлавы. *Яшь юкә кабыгын суеп алып, өске кара элпәсен юнып төшерәсең дә аны тартар гына тасмаларга теләсең.* М.Әмир. *Карыйсың: бераздан, язгы кичнең юка бозы шикелле, яраның өстен күренер-күренмәс юка гына элпә тартып, чыйратып та өлгергән...* Г.Бәширов. *– Су өстен нефть элпәсе каплагач, балыкларга кислород җитми, дип укыганым бар, – диде Таймас.* А.Тимергалин

4) *күч.* Берәр нәрсәне каплап, ышыклап торган, томан, төтен кебек үтәкүренмәле нәрсә; өртү. *Баеп барган кояш та, сыек зәңгәр элпә белән өретелгән күк тә аларныкы ---.* А.Гыйләҗев

**ЭЛПӘ́КАНАТЛЫЛАР** *и. күпл. зоол.* Ике пар үтәкүренмәле элпә канатлары булган, авыз аппараты кимерүгә яки кимереп ялауга көйләнгән бөҗәкләрнең 300 меңләп төрен (бал кортлары, шөпшәләр, кырмыскалар, мөгезкойрыклар һ.б.) берләштергән отряды; *русчасы*: **перепончатокрылые**. *Элпәканатлы-*

*ларның күп кенә вәкилләре кеше өчен файдалы һәм табигатьтә зур әһәмияткә ия.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы. *Элпәканатлылар арасында иң кызыклылары – күмәкләшеп яшәүче кырмыскалар, бал кортлары, шөпшә һәм төклетуралар.* Биология

**ЭЛПӘЛӘНҮ** *ф.* Элпә белән каплану. *Таң атты, карыйбыз – елга өсте юка боз белән элпәләнгән.* М.Мәһдиев. *Бу сүзләрдән Әминә Хөрмәтовнаның төсе үзгәрде, күзләре элпәләнде.* Ф.Яруллин. *Күксел күләгәләр бишегендә Элпәләнә бәллүр яктылык.* Х.Бәдигый

**Элпәләнеп тору** Әле, хәзерге вакытта элпәләнү. *«Моржлар» боз белән элпәләнеп торган салкын су аркылы аркан да тартышты, әлеге бәйгедә матурлык җиңде: гүзәл затлар эһ дигәнче баһадирларны суга тартып төшерде.* Әлмәт таңнары

**ЭЛПЕ** *и.* Хайван имчәге башы. *Сыерыбызның элпесе кутырлаган*

**ЭЛҮ** *ф.* 1) Әйберне салындырып, асып кую. *[Җәмилә] аптырагач, аргы очның чишмә суы яхшы, дигән сәбәп белән, чиләкләрен яшел көянтәсенә элеп, почта буеннан әйләнеп килде.* Ф.Яхин. *Каршыдагы кибет витринасына бик матур күлмәк элгәннәр.* А.Хәсәнов. *Интернат эшеннән бушауга, Әлфинур керләрен юып чыгарып элде.* З.Фәйзи

2) Бәйләп, беркетеп, салындырып калдыру. *Ирләре һәлак булган хатыннар, кара хәбәргә әле дә ышанмыйча, әчке бер өмет белән, өянке ботакларына үзләре чиккән кульяулыкларны элделәр.* М.Галиев

3) Вертикаль өслеккә беркетү. *Аннан соң, доктор кушуы буенча, «Дневальныйның хәлен белү өчен каютага керергә ярамый» дип язып, ишеккә элдерү элде.* М.Юныс. *Район аптекасыннан кирәкле даруларны һәм инструментларны сатып алды, хәтта пыялага «Язтургай медпункты» дигән язу да язып элде ---.* Ш.Бикчурин

4) Тагу, беркетү. *Исламнурның бары тик яхшылык кына тулган киң күкрәгенә ике ел саен орден юкка гына элмиләр шул!* А.Гыйләҗев. *Тагын нишләргә кирәк соң? --- Ә-ә, йозакны элергә кирәк. Бикле дип уйласыннар.* Р.Зәйдулла

5) Берәр җиһаз, аппарат һ.б.ларның алына торган өлешләрен урынына кайтару, кую. *– Ярый алайса, үз вакытым белән килеп чыгармын, хушыгыз! – дип, трубканы элде.* З.Дәүлитов. *Мин кайдан, кем шылтыратуын сорагач, җавап бирмичә, телефон трубкасын элеп куйды.* С.Сабиров

6) Нәрсәне дә булса берәр әйбернең очына гына эләктереп алу. *Балкашык очына гына элеп, әз генә тоз салды.* Р.Батулла. *Кунак тирән итеп суалды да шытырдатып кыяр чәйнәргә кереште, ипи белән йомырка тәбәсе элеп капты ---.* Ф.Садриев

7) *сөйл.* Ничек туры килсә шулай, тиз генә, туры килгән теләсә нәрсәне кию. *«Тагы ниләр майтарды икән инде?» – дип, өстенә йон кофтасын киеп, аягына тирән галошын гына элде дә --- югары очка ашыкты.* А.Вергазов. *Ә кунак исә, аягына элеп алган йомшак чүәкләрне өстерәп, янә балконга чыгып басты.* Э.Касыймов

8) Гомумән кию. *Якыная башлагач, мин аның аксак икәнлеген һәм киң, җәлпәк борынына кысасы тузып, җеп белән уратылып беткән күзлек элгән булуын күреп алдым.* А.Гыйләҗев. *Ә монда йокы урынына, түләнмәгән бурыч кебек, Урмановның ясалма маска элгән йөзе күз алдына килә ---.* Т.Галиуллин

9) Кидерү. *Җик мәргән җәясенә ук артыннан ук элде.* М.Хәбибуллин. *– Менә, акыллым, сине хөрмәтләвемнең бәләкәй генә бер билгесе булсын, – диде дә Мортаза хатынының бармагына бик тә нәфис йөзек элде.* К.Тимбикова

10) Эләктереп алу. *Малай, күзен елтыратып, кача башлаган иде, Зиннур аның җилкәсеннән элеп алды.* А.Гыйләҗев. *Карчыга бәпкәне элгән*

11) Элгеч белән бикләү. *Шәйхи хәлфә ишекне эчтән элде.* М.Мәһдиев // Келәне махсус эшләнгән элгеченә эләктерү. *Ишекне бикләгәч, ул урамга чыгып капканы элде.* З.Мәхмүди

12) *сөйл.* Нәрсәгә дә булса ут алдыру, яндыру. *Әкълимә карчык почмак тирәсендә кайнаша, кулларында савытсаба уйный, учагына ут та элгән.* Н.Хәсәнов. *Солтан ул нык, коры имән утыннарын яңа урынга учак итеп тергезде, аларга нарат ботакларын өстәде, чыра телеп, ут элде.* Ә.Гаффар

13) *неол.* Берәр мәгълүматны сайтка, порталга һ.б.га урнаштыру

14) *күч.* Тиз генә алу, каптыру, урлап алу, чәлдерү. *Тычкан --- үзе кеби кечкенә генә бер ит кисәген элде дә алды-артына карамый сызды.* Г.Тукай

◊ **Элеп алу** 1) Сүз белән каты һөҗүм итеп, тиргәп, хурлап ташлау. *Сары кашлы, сипкелле битле чандыр гына бер хатын, урыныннан торып, тегеләрне элеп алды.* Г.Толымбай. *– Аптырыйм, җан да бар икән үзегездә! – дип элеп алып китте ак чырай янәшәсендә җәелеп утырганы.* Р.Мулланурова; 2) Берәр мәсьәләне тотып алып, шул турыда сөйләп китү, дәвам иттерү; 3) Ялмап алу, янып китү. **Элеп алып** Җиңел, кызу адымнар белән атлап, чабып. *Шәмсинең сикереп менүе булды, атлар тагын элеп алып чаба башладылар.* Г.Бәширов. **Элеп алып селкеп салу** 1) Кешенең яманатын, гайбәтен сату. *– Мине яклап чыкканың өчен... рәхмәт. Шулай шул, кеше теленә бер эләксәң, элеп тә алалар, селкеп тә салалар, – [диде Талия].* М.Маликова; 2) Бик каты ачулану, пыр туздыру. *Үзен дә элеп алып селкеп салдылар: – Әй, Әхмәт түгел, зәхмәт булдың әле син!..* М.Хәсәнов. **Элеп киптергән кебек (-мени, шикелле)** Бик ябык, арык. *Бүлмәгә биш малай урнаштык. Беребез – элеп киптергән балык кебек юка йөзле, иләмсез күзлекле мишәр малае --- [иде].* Р.Вәлиев. *Миңа, теге дөньядан кайткан адәмгә карагандай, күзен чекерәйтеп карап торды да, коты очып: – Бөтенләй корышкансың, элеп киптергән кебек булгансың.* Г.Мөхәммәтшин. *Кайчагында --- әйтеп китәм ---, кайнар ризык пешер, дим. Юк бит, --- я духовкага бәрәңге тәгәрәтә, я булмаса, кабыгын да әрчемичә, ярып кына табага куя. Шуңа күрә анә үзе дә... элеп киптергәннәрмени!* Г.Шәрәфи. **Элеп тә бирмәү** Тыңламау, игътибар итмәү. *Аңлаган кешегә бик аңлаешлы итеп әйтә дә бит, юк! Әнә элеп тә бирми, таш сын кебек катып тик тора.* М.Хәсәнов

**Элә башлау** Элергә тотыну. *Ул өй алдында пәлтәсен элә башлый, тик элә алмый.* Х.Ибраһим. *– Артык, син кем атларын урладың? – дип эндәште аңа Җик, ә үзе җәясенә ук элә башлады.* М.Хәбибуллин

**Элеп бетерү** Барысын да, беткәнче элү. *Гөлйөзем, керләрен янбакчадагы бауга элеп бетереп, ишегалдына чык[ты] ---.* З.Хөснияр. *Шул искелекне томаларга тырышыптыр, стена тутырып плакат, таблицалар, лозунглар элеп бетергәннәр иде.* А.Гыймадиев

**Элеп кую** Элгән хәлдә калдыру; алдан элү. *Куркынычсызлык каешын элеп куйганда, ялгышымы, ирексездәнме, алдан уйланылганчамы, кулы кызның күкрәгенә өстеннән үтте.* Т.Галиуллин. *Бүлмәнең ишеген эчтән элеп куйганнан соң, Билал байтак кына вакыт, әнә шуларны*

*күздән кичерә-кичерә, бер хәрәкәтсез тыныч кына басып торды.* М.Вәлиев

**Элеп чыгу** Башыннан ахырына кадәр, бер-бер артлы элү. --- *буш какакларга киемнәрне элеп чыктылар.* Р.Батулла. *Әгәр ул бөтен шәһәр буенча белдерүләр элеп чыкса?* Г.Гыйльманов

**ЭЛҮЛЕ** *с. сир.* **1.** Элеп куелган. *Элүле пәрдә*

**2.** *рәв. мәгъ.* Элеп куелган хәлдә. *Стенаның сул ягына берничә агач кадалган, боларда камытлар, йөгәннәр, иярләр элүле тора.* Г.Ибраһимов

**ЭЛЬДОРА́ДО** *и. исп.* 1) Америкада беренче испан басып алучылары эзләгән алтын һәм кыйммәтле ташларга бай хыялый ил

2) *күч.* Байлык иле; могҗизалар иле

**ЭЛЬФ** *и. нем. миф.* Борынгы герман-скандинав мифологиясендә кеше кыяфәтендә күзалланган әйбәт табигать рухы. *Кәрләләр риваятьләргә төрле исемнәр белән: феялар, гномнар, эльфлар булып кереп калганнар.* Файдалы киңәшләр

**ЭЛЮВИАЛЬ** *с.* Составында элювий булган; элювийдан гыйбарәт булган. *Ә инде тау башларында, акмыйча, урынында калган таш кисәкләренә, ком бөртекләренә элювиаль утырмалар диләр.* А.Фәткуллин

**ЭЛЮ́ВИЙ** *и. лат. геол.* Тау токымнарының җилдә ашалуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән, әкренләп төп токымга әйләнә барган, токымнарның төрле зурлыктагы кисәкләреннән торган механик катнашма

**ЭМ** *ы.* 1) Сузыбрак әйтелеп, икеләнүне, гаҗәпләнүне, шикләнүне, ышанмауны, килешмәүне, янауны һ.б.ш. белдерә. *[Лариса]: Эм... Менә ничек! Әдәбият түгәрәге оештырганнан соң, син гел поэзия теле белән генә сөйли башлагансың икән.* Т.Гыйззәт. *Гази, --- кашыктагы балык шулпасын авызына күтәрү белән, янә аваз салды: – Эм-м-м!.. Телләрне йотарлык булган ич бу, Гаделша бабай.* М.Хәсәнов

2) Сөйләшкәндә нәрсәне дә булса әйтергә авырсынып, уңайсызланып калуны белдерә. *Гәрәй ни әйтергә белмичә бераз уйланып торганнан соң: – Эм... болай гына, – дип, ык-мык итеп куйды.* С.Сабиров

**ЭМАЛЬ** *и. фр.* **1.** 1) Тышкы тәэсирләрдән саклау өчен, металл әйберләрне каплап, яндырып ныгытыла торган пыяласыман ялтыравык масса

2) Шундый масса белән бизәк төшереп, каплап сәнгать әйберләре ясау ысулы; шуның төрләре. *Көндәлек тормыш әйберләренә эмаль, глазурь, төрле төстәге лаклар төшерү, чигү, ташка, бамбукка, фил сөягенә сырлап (уеп) бизәкләр ясау кебек эшләр башлана.* К.Гыйззәтов

3) Шундый масса белән капланган, йөгертелгән, ялтыратылган әйбернең үзе

4) Керамика әйберләрен каплый торган глазурь, ялтыравык катлам. *Пётр килә: Митрийның идән тулы, өстәл асты тулы бала, ишек катында яшел эмаль тышлы саплы чүлмәк кенә икеәч.* М.Мәһдиев

5) *полигр.* Челтәрле клишеның кислотага бирешми торган пыяласыман өслеге

6) *анат.* Тешнең тышкы ягын каплап алган, нигездә минераль тозлардан торган, ялтыравык ак каты катлавы. --- *тешләр бик каты эмаль белән капланганнар.* Зоология. *Ул [фторлы паста] – кариес булдырмауда һәм тешнең эмален саклауда иң нәтиҗәле чараларның берсе.* Юлдаш

7) Хуҗалыкта кулланыла торган тиз кибүчән ялтыравык буяу төре

**2.** *с. мәгъ. к.* **эмальле** (*1 мәгъ.*). *Эмаль чәйнек белән чәй дә кайнатып керттем ---*.Ә.Еники. *Операция сестрасы зур ак эмаль тазга шалтыратып инструментларны тутыра башлады.* М.Маликова. *Зәнфирә аракыны эмаль кружка төбенә салды.* Ф.Садриев

**ЭМАЛЬЛӘ́Ү** *ф.* Эмаль белән каплау

**Эмальләп алу** Кыска вакыт эчендә эмальләү

**Эмальләп кую** Тиз генә эмальләү

**ЭМАЛЬЛЕ** *с.* 1) Эмаль белән капланган. *Майҗамалттәй --- суны эмальле зур чиста табакка салды ---*. М.Мәһдиев. *Апа --- эмальле чиста таска казаннан җылымса су салып бирде.* Н.Фәттах

2) Составында эмаль булган. *Эмальле буяулар*

**ЭМАНСИПА́ЦИЯ** *и. лат.* Бәйлелектән, изелүдән, юк-барга ышанулардан, хорафатлардан азат булу; чикләрне бетерү, хокукларны тигезләү. *Ә менә хатын-кыз депутатлар бу съездда аз булган: нибары 21 кеше. Эмансипация, күрәсең, әле уянып кына килгән чор...* Р.Фәйзуллин. --- *[пропаганда] наданлыкны бетерү өчен көрәш, хатын-кыз эмансипациясе, яшүсмерләргә урамның начар йогынтысы да бар.* Р.Сверигин

**ЭМАНСИПА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Эмансипация ясау, кемне яки нәрсәне дә булса берәр бәйлелектән азат итү

**ЭМБА́РГО** *и. исп.* 1) Дәүләтнең башка ил тарафыннан алтын, валюта яки кайбер товарлар (мәс., корал) кертүне яки чыгаруны рәсми тыюы. *Бу мәсьәләне дипломатик каналлар аша да хәл итәргә тырышып караганнар, әмма зур акчаларга килеп терәлгәч, халыкара санкцияләрдән курку да бетә, дөньяның кайнар нокталарына салынган эмбарго дигәннәре дә онытыла.* Р.Мирхәйдәров

2) Төрле сәбәпләр аркасында чит ил дәүләтләренең судноларын, товарларын портка кертми яки порттан чыгармый тору

3) Халыкара иминлеккә куркыныч тудырган дәүләткә карата коллектив репрессив чара, басым ясау формасы буларак аның белән сәүдәне тыю

**ЭМБЛЕ́МА** *и. гр.* Берәр төшенчәнең яки идеянең шартлы символик сурәте, әйбере, билгесе. *Икенче көнне зәңгәр фуражкалы, козырёгы өстенә алтын нәкыш эмблема куелган таза гына гәүдәле кеше барыбызны да сафка тезде һәм үзе белән таныштырды.* Х.Камалов. *Блокнот битенең астына ул десантниклар эмблемасы ясап куйган иде.* Р.Вәлиев

**ЭМБОЛИ́Я** *и. гр. мед.* Кан яки лимфа агымы белән күчеп йөри торган газ куыклары һәм ит кисәкчәләре белән кан һәм лимфа тамырларының томалануы. *Ләкин анализ канның артык майлы булуын күрсәтә. Эмболия куркынычыннан сакланып, авыруга үз канын бирмәскә булалар.* С.Сөләйманова

**ЭМБРИОГЕНЕЗ** *и. гр. биол.* Организмнарның эмбриональ үсеш процессы. *Өченче һәм дүртенче бүленүдән соң, барлык 8 яисә 16 күзәнәк тә нормаль үсә башларга мөмкин, әмма яралгылар, гадәттә, эмбриогенезның баштагы стадияләрендә һәлак булалар.* Кызыклы физиология

**ЭМБРИО́ЛОГ** *и. гр.* Эмбриология белгече. *Хәзерге эмбриологларда югары имезүчеләрдә сары матдә капчыклары ясалу аңлашылмаучанлык тудыра: соңгылык (плацента) үскән саен, сары матдә кирәкми башлый, һәм яралгы соңгылык аша гына туклана.* Фән һәм тел

**ЭМБРИОЛО́ГИК** *с.* Эмбриологиягә хас, эмбриологиягә бәйләнешле. *Эмбриологик тикшеренүләр төрле төрдәге хайван яралгыларының төзелешендә бигрәк тә зур охшашлык булуын күрсәтте.* Дарвинизм һәм дин

**ЭМБРИОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Биологиянең хайван һәм кеше яралгысы үсешен өйрәнә торган бүлеге. *Эмбриологиянең барлыкка килүе бик күп яңалык китерде.* Дарвинизм һәм дин. *Аналыкның өч*

*каттан торганы микроскоплар, рентгеннар, ультратавышлы җиһазлар, эмбриология, физиология, урология фәннәре үскәч кенә мәгълүм булды.* Сөембикә

**ЭМБРИОН** *и. гр.* 1) Организм үсешенең иң башлангыч чоры; яралгы. *Камерада эмбрионның үсеше өчен кирәкле температура һәм дымлылык саклана.* Биология. *Эмбрион үсешенең билгеле бер стадиясендә [умырткалы хайваннар] миенең ике кисәге башка өлешеннән аерылып чыга да акрынлап күзләргә әверелә.* Кызыклы физиология

2) *күч. кит.* Нинди дә булса әйбер, фикер, идея һ.б.ш.ның башлангычы, яралгысы. *Безнең авыл халкында бүгенге промышленность тармакларының бик күбесе эмбрион хәлендә елекелектән яшәгән.* М.Мәһдиев

**ЭМБРИОНАЛЬ** *с. биол.* 1) Эмбрионга хас; эмбрион хәлендәге. *Эмбриональ үсеш беркадәр бу тарихи күренешне чагылдыра.* Дарвинизм нигезләре // Эмбрион булган. *Эмбриональ күзәнәк*

2) *күч. кит.* Нинди дә булса үсешнең, процессның иң башлангыч, яралгы хәлендә булган. *Х.Туфанның алда күзәтеп үткән язмаларында без шагыйрьнең беренче сызмаларында ук күп төрле үлчәм яралгылары очрап куюын, ахырдан шул эмбриональ (яралгы) үлчәмнәрнең тик берсенең генә файдаланылуын күреп үттек.* Н.Юзиев. *Җәмгыятьтә, эмбриональ хәлдә булса да, демократик чалымнар барлыкка килде.* Р.Фәйзуллин

**ЭМИГРАНТ** *и. лат.* Үз ватаныннан чит илгә мәҗбүри яки үзе теләп күчеп киткән кеше, эмиграциядәге кеше. *Шул вакытта аңа ак эмигрант Гаяз Исхаков та котлау телеграммасы җибәрә.* М.Галәү. *Узган ел Истамбулда булырга туры килгән иде. Шунда бер эмигрант белән очраштык.* М.Галиев

**ЭМИГРА́ЦИЯ** *и. лат.* 1) Сәяси, икътисади, дини һ.б.ш. сәбәпләр аркасында бер илдән икенче илгә мәҗбүри рәвештә яки үз теләге белән күчеп китү. *Элек вакытта революцияче эмиграция үзәге булган, --- Пасси кварталлары хәзер рус контрреволюциясе почмагына әйләнгәннәр.* Г.Гобәй. *Доктор Эренжен Хар-Даван – милләте белән калмык. «Чыңгызхан полководец һәм аның мирасы» дигән хезмәтен революциядән соң, эмиграциягә китеп, Югославиядә язган.* А.Хәсәнов

2) Мәҗбүри рәвештә яки үз теләге белән күчеп китеп, ватаннан читтә яшәү хәле. *Бер монда гына түгел, анда – эмиграциядә дә, Ленинча әйтсәк, шул ук развал, распад, идейно-политический разброд хөкем сөрә.* Г.Ибраһимов. *Эмиграциядәге бөтен гомерен татар халкының азатлык көрәшенә багышлап, үзенең туган халкы өчен җан атып, --- иҗат итеп, көрәшеп, батырлыкның да батырлыгын күрсәткән изге бөегебез ул безнең!* Б.Рәхимова

3) *җый. и.* Күчеп китеп, чит илдә яшәүче кешеләр, эмигрантлар

4) *физиол.* Кеше яки хайваннарның кан тамырлары тирәсендәге тукымалар ялкынсынуы нәтиҗәсендә лейкоцитларның һәм эритроцитларның кан тамырлары тышчасы аша үтеп чыгуы

**ЭМИССАР** *и. лат.* Аерым сәяси яки дәүләт оешмалары тарафыннан (күбесенчә яшерен эш белән) башка илгә җибәрелгән кеше. *Ни майтарып йөри биредә Рәсәй президентының эмиссары?* Т.Галиуллин. *Чекист халкы һәрвакыттагыча артык уяулык күрсәтер: чүплек башларыннан, фәхешханәләрдән эзләр. Әмма шәһәр уртасында Махно эмиссары --- яшәп ятыр дип башына да китерә алмас.* З.Фәтхетдинов

**ЭМИССИОН** I *с. лат.* Эмиссиягә (I) караган. *Эмиссион салым*

**ЭМИССИОН** II *с.* Эмиссия (II) ярдәмендә эшли торган. *Термоэлектрон эмиссия электрон лампаларының эше нигезендә ята.* Даими ток законнары. *Эмиссион анализ*

**ЭМИ́ССИЯ** I *и. лат. махс.* Дәүләт тарафыннан яки аның контроле астында акча һәм кыйммәтле кәгазьләрне әйләнешкә чыгару. *Күпме шауламасыннар анда, инфляция, эмиссия, деноминация, дефолт дип куркытмасыннар, эшләгәне икмәккә май ягып ашарга җитә иде Илшатның, балаларының өсте бөтен, тамаклары тук иде.* К.Кара

**ЭМИ́ССИЯ** II *и. лат. физ.* Җылытудан яки тышкы электр һәм электромагнит кырлары тәэсиреннән кайбер матдәләрнең фотон, электрон, ион һ.б. кисәкчәләр бүлеп чыгаруы. *Термоион эмиссиясе. Термоэлектрон эмиссиясе. Электрон эмиссиясе. Автоэлектрон эмиссиясе*

**ЭМИ́ССИЯЛӘҮ** *ф. икът. ялг.* Эмиссия ясау, эмиссия үткәрү. *Халык хуҗалыгын эмиссияләү*

**ЭМИТЕНТ** *и. лат. фин.* Кыйммәтле кәгазьләр, банк билетлары, кәгазь акчалар чыгару хокукы булган учреждение, банк

**ЭМОЦИОНАЛЬ** *с.* 1) Эмоцияләр белән бәйле, шул өлкәгә караган. *Музыкада эмоциональ реакциянең ике ягы: шартсыз һәм шартлы рефлектор яклары бар.* Кызыклы психология

2) Хис-тойгыларга бай, тәэсирле, кайнар; эмоцияләрне белдерә торган. *Ул җыр сүзләренең тирән эчтәлеген, эмоциональ көчен ача белә.* Ә.Айдарская. *Совет Армиясенең бу уңышларын шагыйрь тирән эмоциональ кичерешләр белән, табигать күренешләре аркылы сурәтли.* Г.Хисмәтуллин

3) Нечкә күңелле, матурлыкка, сәнгатькә, хискә сизгер. *Шамилнең гомерлек хезмәте эмоциональ иҗат кешеләре – артистлар, язучылар, композиторлар белән үтсә, Ринат тормышының байтак өлеше рәсми кешеләр – төрле рангтагы җитәкчеләр, чиновниклар даирәсе белән бәйле.* Әдәбият

4) Эмоциягә, хис-тойгыларга тиз бирелүчән, сабырсыз, тиз ярсучан, кызып китүчән

**ЭМОЦИОНАЛЬЛЕК** *и. к.* **эмоциялелек**. *Аңа [Хәмидәгә] да эмоциональлеген югалткан сөйләм артыннан иярү кыен ахры, вакыт-вакыт чыраен сытып, иренен тешләп, игътибарын соң чиккәчә көчләп азаплана.* А.Вергазов. *Шәхеснең эмоциональлеге һәм аның темпераменты, төрле субструктураларга керсәләр дә, бер-берсе белән тыгыз бәйләнгәннәр.* Кызыклы психология

**ЭМО́ЦИЯ** *и. лат.* Хис, тойгы, кичереш һәм шуның чагылышы. *--- ул [Минҗан карт] беркайчан да, бер мәртәбә дә көлмәгән, елмаймаган кебек, беркайчан зарланмады да. Табигать, күрәсең, андый эмоцияләрдән аны азат иткән.* М.Мәһдиев. *Артык эмоция сәламәтлеккә зарарлы.* Т.Миңнуллин

**ЭМО́ЦИЯЛЕ** *с.* **1.** 1) Эмоциягә бай булган, тәэсирле, хисле. *Шигырьнең сүз сәнгате булуын да онытырга ярамый. Ул тылсымлы эчке агышлы, эмоцияле, ачык һәм олы образлы булырга тиеш.* Ә.Габиди

2) Эмоцияләре көчле чагылган, тыштан күренеп торган, эмоцияләрен яшерми торган, кайнар. *Музыка язучыларның иҗат процессында күтәренкелек, гадәттән тыш эмоцияле халәт кичерүләре мәгълүм.* К.Гыйззәтов. *– Моннан соң ---, Хатип Госман күзенә азрак юлыгырга тырыш. Ул шундый инде, эмоцияле кеше, – диде И.Нуруллин.* М.Гайнетдинов

**2.** *рәв. мәгъ.* Хисләнеп, эмоцияләрен тыймыйча; тәэсирле итеп. *Әлбәттә, лекцияләрнең эчтәлекле булуы мөһимрәк.*

*Ләкин аларны лектор эмоцияле итеп укый да алса, тагын да яхшырак.* К.Гыйззәтов

**ЭМО́ЦИЯЛЕЛЕК** *с.* Эмоцияле булу, хислелек, эмоциягә, тойгыга бирелүчәнлек; сабырсызлык. *Яшьләр мәхәббәтенә көчле эмоциялелек хас булса, олырак яшьтәгеләр өчен акыллылык, дөрес фикер йөртүчәнлек, хисләрнең сабыр характерда булуы хас*. К.Гыйззәтов

**ЭМПИРЕЙ** *и. гр. кит.* 1) Борынгы грекларның космогоник күзаллаулары буенча, күкнең ут һәм яктылык белән тулган иң югары өлеше

2) *күч.* Хыял диңгезе, хыялый урыннар

**ЭМПИРИЗМ** *и. гр. филос.* 1) Танып белүнең бердәнбер чыганагы бары тик тәҗрибә генә, дигән карашны алга сөреп, фәнни гомумиләштерүне, логик анализны кире кага торган фәлсәфи тәгълимат. *Инглиз философлары Бэкон, Һоббс һәм Локк --- фәлсәфәдә эмпиризм тарафдарлары буларак, иҗатны хаклы рәвештә тәҗрибәләр нигезендә уйлап чыгару эшләре белән бәйлиләр*. К.Гыйззәтов

2) *кит.* Теориянең, фәнни гомумиләштерүнең әһәмиятен танымыйча, аңа зыян китереп, фактларга һәм тәҗрибәләргә бирелгәнлек

3) Гамәли эшчәнлек

**ЭМПИ́РИК** I *и. рус филос.* 1) Эмпиризм (*1 мәгъ.*) тарафдары

2) *кит.* Эмпиризмны (*2 мәгъ.*) яклаучы, гамәли эшчәнлек белән мавыгучы кеше

**ЭМПИ́РИК** II *с. кит.* 1) Эмпиризм карашларын эченә алган, эмпиризмга нигезләнгән, эмпиризмга бәйләнешле. *--- бала уйлау-фикерләүнең югары дәрәҗәсенә – теоретик, образлы, диалектик фикерләүләргә, конкрет тарихи, эмпирик фикерләүләргә омтылырга, фикерләүнең әлеге алымнарының барысына берьюлы ия булырга тиеш.* Ә.Хуҗиәхмәтов

2) Эмпириягә (*1 мәгъ.*) нигезләнгән. *--- безнең фәнни әдәбиятта сәнгати фикерләүне танып белү процессының рациональ баскычыннан, эмпирик фактларны абстракцияләү актларыннан аерып карау очраклары күзәтелә*. К.Гыйззәтов. *Әсәрнең асылында, эмпирик (хисләр ярдәмендә) танып белә ала торган яшәештән тыш, камил яшәеш турындагы карашлар ята ---*. А.Шәмсутова

**ЭМПИ́РИКЛЫК** *и.* Эмпиризмга нигезләнгәнлек, эмпиризм белән сугарылганлык

**ЭМПИРИОКРИ́ТИК** *и. рус филос.* Эмпириокритицизм тарафдары

**ЭМПИРИОКРИТИЦИЗМ** *и. филос. рус* XIX гасыр ахырында Р.Авенариус тарафыннан нигез салынган субъектив-идеалистик агым. *1908 елны «Материализм һәм эмпириокритицизм» дигән хезмәтендә ул [Ленин] «кеше турында --- аның эшләренә карап хөкем йөртәләр» дигән фикергә әйләнеп кайта.* Кызыклы психология

**ЭМПИРИОМОНИЗМ** *и. рус филос.* Эмпириокритицизмның бер төре

**ЭМПИРИ́Я** *и. гр.* 1) *филос.* Кешенең тышкы дөнья белән мөнәсәбәтләре һәм үзенең сизү, фикер йөртү һәм психик эшчәнлеге нәтиҗәсендә тупланган белем һәм тәҗрибә

2) Эксперименттан аермалы буларак, табигый шартлардагы күзәтүләр

**Э́МУ** *и. португ. зоол.* Казуарсыманнар отрядыннан Австралиядә һәм Тасмания утравында яши торган зур кош. *Австралия саванналарында соры тәвә кошы – эму яши ---*. Физик география. *Кошлардан Австралия фаунасы өчен типик булган һәм монда гына очрый торган тәвә кошларның аерым формалары (казуар һәм эму) --- бар.* Дарвинизм нигезләре

**ЭМУЛЬГА́ТОР** *и. лат.* Эмульсия әзерләүне җиңеләйтә, аны тотрыклыландыра, сыеклык тамчылары берләшүне булдырмый торган матдә (мәс., сабын, казеин, желатин һ.б. матдәләр). *Эмульсиянең тотрыклылыгына ирешү өчен, аңа эмульгатор кертелә.* Төзү материаллары. *Өстәмәләр кушылмаган шоколадның төп ингредиентлары булып какао порошогы, какао мае, шикәр, эмульгатор (лецитин), хушисләндергечләр тора*. Мәдәни җомга

**ЭМУ́ЛЬСИЯ** *и. лат.* 1) Нинди дә булса сыеклыкның эреми торган кисәкчекләре белән туендырылган сыекча. *Ә һәр ел саен чыгарылган нефтьтән 300 мең тонна шлам, 50 мең кубометрдан артык нефть катнашкан сулы эмульсия һәм башкалар калуын әйтмибез.* Ф.Яруллин. *Әгәр эретүчедә --- сыекча тамчылары йөзеп йөрсә, бу эмульсия була.* Химия

2) Төгәл дозасы билгеләнмәгән сыек дару формасы

3) Фотографиядә кулланыла торган кайбер материаллар өстендәге яктылыкка сизгер катлам

**ЭМФА́ЗА** *и. гр.* 1) *әд.* Төрле риторик фигуралар куллану, интонацияне үзгәртеп тору белән сөйләмнең тәэсирле, күтәренке рухта булуын тәэмин иткән алым. *Заман формаларын контекстта өйрәнү нәтиҗәсендә аларның күпмәгънәлелеге, үзара бәйләнешләре, эмфаза --- буларак кулланыла алуы ачыклана.* Татар грамматикасы

2) *лингв.* Кайбер тартык авазларны әйтүдә сизелә торган киеренкелек

3) Текстның аерым урыннарына игътибарны юнәлтү өчен, аларны берәр төрле – төс, курсив һ.б.ш. белән аерып күрсәтү алымы

**ЭМФА́ТИК** *с.* 1) *әд.* Үтә тәэсирлелек, сәнгатьлелек белән аерылып торган

2) *лингв.* Аеруча киеренке әйтелешле (авазлар тур.). *Рәт гармониясе, ягъни сузыкны калын яки нечкә итеп уку, гарәп теленең эмфатик хәрефләренә нигезләнә.* Татар әдәби теле тарихы

**ЭМФИЗЕ́МА** *и. гр. мед.* Сулыш алу органнарында бушлыкларның кирәгеннән артык киңәюе, зураюы, андагы тукымаларның сузылуы һәм уцыны белән өзелүеннән гыйбарәт авыру

**ЭНӘ** *и.* 1) Бер башы очлы, икенче башында җеп тагу өчен тишек (күз) ясалган, тегү-чигү эшендә кулланыла торган кыска, шома, нәзек корыч чыбык рәвешендәге кул эше коралы. *Сәкинә түшенә кадаган энәсен, нишләтергә белмичә, әле тартып алды, әле яңадан кадады.* Ф.Яруллин. *Кайдандыр бераз спирт юнәткән дә, тегү энәсен шуңа манчып, кызларның колак яфрагын тишә.* А.Вергазов // Тегү машинасында очлы башында җеп үткәрү өчен тишеге, икенче яртысында киртләче булган кыска корыч чыбык рәвешендәге деталь. *Аның бабасы Гали абзый, сугыш беткәч, Германиядән бер капчык зажигалка ташы һәм «Зингер» дигән тегү машинасы энәсе алып кайтты һәм шуны сатып баеган иде шул.* М.Галиев

2) Бәйләү өчен хезмәт итә, ике яки биш данә итеп кулланыла торган, ике очы да шома тупыйк башлы нәзек корыч (эрерәкләре – агач, пластмасс) чыбык рәвешендәге кул эше коралы. *Хуҗа ханымның кулында йон йомгак, бәйләү энәләре пәйда булды.* А.Хәсәнов. *– Туй сиңа! – Маһинур ачы тавыш белән кычкырып җибәрде дә кулындагы бәйләп утырган оекбашын идәнгә атып бәрде. Энәләр төрле-төрле якка чәчрәделәр.* И.Салахов

3) Бәйләү, чигү эшләрендә кулланыла торган, бер башы ыргак сыман итеп эшләнгән нечкә корыч яки пластмасса чыбык рәвешле корал

4) Уйнату җайланмаларында тавыш алгыч буларак кулланылган бер башы очлы нәзек корыч чыбык рәвешендәге деталь. *Патефон энәләре аңкауга, теш төпләренә кадалдылар ---.* М.Мәһдиев

5) Тән тукымасы арасына дару җибәрү, венадан кан алу өчен кулланыла, тирене тишеп үтә торган очлы башлы нечкә көпшә рәвешендәге медицина коралы. *Ася, Әнвәрнең беләгеннән кан тамырын табып, аны ышкый-ышкый кабарта иде. Анна Сергеевна шул урынга тизрәк шприц энәсен кертеп җибәрде.* Х.Камалов. *Энәсен өскә күтәреп, даруын сиптерә-сиптерә, кошлар уянганчы ук бүлмәгә килеп кергән шәфкать туташы яңа көн исәбен ваклап җибәрә.* Т.Галиуллин // Организмны тиредәге билгеле нокталарга кадап дәвалау – акупунктура ясау өчен кулланыла торган үткен нечкә металл чыбык рәвешендәге медицина коралы. *Энә терапиясе, мануаль массаж, кислород коктейльләре һәм башка шундый сирәк очрый торган савыктыру ысуллары бик яхшы нәтиҗә --- бирә.* Ф.Фәткуллин

6) Ылыслы агачларның яфрагы; ылыс. *Су җиленнән, ухадан, коенудан ялыксак, дачаларга ук авып торган күгелҗем нарат урманнарына юл табыз, -- нарат энәләреннән тукылган хуш исле келәмгә ятып, тагын хыялларга биреләбез...* А.Гыйләҗев. *--- төпләре кызыл энә белән тулы, кәүсәләрен зәңгәр сакал баскан карт кара чыршыларның берсе котчыккыч чиркәнеч тавыш белән шагырдап ала ---.* М.Мәһдиев

7) Кайбер үсемлекләрдә вак кына чәнечке, шырпы. *Ашыгуыннан куак энәләре бармакларын чәнчеп бетерде ---.* Р.Төхфәтуллин. *Акбай чинап җибәрде, --- шайтан таягына баскан икән ---. Малай этнең тәпиен күтәреп, табанына кадалган саргылт энәләрне тартып чыгарды.* Р.Бәшәр

8) Кайбер хайваннарның тәннәрендәге кыска каты, чәнечкәле кыл, үсенте. *--- егетнең кыска гына итеп кыркылган чәчләре, керпе энәләредәй, үрә басып тора.* Ә.Еники. *Чәчләр керпе энәсе кебек үрә торган. Пилотка күтәрелгән.* М.Мәһдиев

9) *күч.* Киная белән, төрттереп әйтелгән, усал, зәһәр сүз

10) *күч.* Наркотик матдә белән укол ясау; гомумән наркотик матдәләр, наркотиклар. *Аннан [вуздан куып чыгарылудан] куркып кына наркоман барыбер энәдән котыла алмый инде.* Мәгърифәт. *Әти-әнисе бик соң белде. Алия энә колына әверелгән иде.* Мәдәни җомга

◊ **Энә белән баз казу** *к.* **энә белән кое казу**. *Алары инде энә белән баз казый: мәгълүмат-фактларны бердәмтекләп җыя, фәнгә бөтен барлыгывөҗүде белән чума.* М.Гайнетдинов. **Энә белән җеп итү** Аерылмас хәлгә китерү, бәйләү. *– Безне энә белән җеп итәләр, ә? – дип, Идрисов --- Мамакка карады.* Х.Камалов. **Энә белән җеп кебек** Гел бергә, бер-берсенә тагылып йөрүчеләр турында. **Энә белән кое казу** Озак һәм зур сабырлык белән эшләнә, ирешелә торган, үрчемсез, авыр эш. *Гәрчә ирем гомер буе мәдәният өлкәсендә энә белән кое казыса да, хәрбиләрдән үзенең һөнәре белән бик-бик ерак торса да, аны әледән-әле бимазалыйлар.* К.Миңлебаев. *Күз алдымда, энә белән кое казып дигәндәй, тырыша-тырыша укып, кеше булдыгыз.* К.Тимбикова. **Энә белән тиресен тунау** Чиктән тыш авыр җәзага дучар итү. **Энә белән чокыр казу** *к.* **энә белән кое казу**. *Бу биналарга, --- энә белән чокыр казып, гыйлем эстәргә, китап актарырга --- ашкынып, җәяү киләләр.* М.Маликова. **Энә бөртеге кадәр** *к.* **энә очы кадәр**. *Уйга калган: баксаң – хуҗалык алдагы ел өчен әзер һәм энә бөртеге кадәр дә эше калмаган икән ---.* М.Мәһдиев. **Энә буе җир китү** Бик акрын кыймылдау, бик аз юл үтү. *Ай китте, ел китте – энә буе җир китте.* Әкият. *Менәсең, аякларың хәрәкәтләнгәндәй була, борылып карасаң – нибары энә буе җир киткәнсең.* А.Гыйләҗев. **Энә булып кадалу** Авыр тәэсир итү. *Аның [Галинең] бу сүзләре күңелнең әллә кай җиренә энә булып кадалды.* Б.Камалов. *Сабыйның ачыргаланып ялвару авазы Харисның бәгыренә энә булып кадалды, баланың авыр минутларда якын кешесеннән мәхрүм булып торуына йөрәге телгәләнде.* Ә.Моталлапов. **Энәгә дә кагылмау** Сораусыз бер әйберне дә алмау; урлашмау. *Утыз ел хуҗасыз картайган йортта энәгә дә кагылмаганнар ---.* Н.Гыйматдинова. **Энәгә дә тимәү** *к.* **энәгә дә кагылмау**. *Әйе, авыл халкы кешенең энәсенә дә тими, нәрсә хәрам, нәрсә хәләл икәнен, иң кадерле мирасның берсе итеп, буыннан буынга тапшыра килгән.* Н.Әхмәтов. **Энәгә күзләгән җеп шикелле** *к.* **энә белән җеп кебек**. *Этнең үзен табу бер дә көтелмәгәнчә мәшәкатьле булып чыкты. Данишев, аны эзләп, энәгә күзләнгән җеп шикелле йөрде.* З.Фәтхетдинов. **Энәгә тагылган җеп кебек** *к.* **энә белән җеп кебек**. *Аннары Мөбинә үзе дә, энәгә тагылган җеп кебек, гел шамакай Илнур тирәсендә уралыр иде.* М.Шаһимәрданов. **Энәгә таккан җептәй** *к.* **энә белән җеп кебек**. *Епископ Савва, энәгә таккан җептәй, аларга иярде.* М.Хәбибуллин. **Энәгә утырту** Кемне дә булса наркотиклар кабул итәргә өйрәтү, наркоманга әйләндерү. *--- аннары аракысыннан авыз иттерде. Алары гына аз тоела, арт саннарына мәзәк җитми башлагач, үләнен тарттырды. Ахыр килеп энәгә утыртты.* Л.Ибраһим-Вәлиди. *Янәшәдәге биш катлы йорта наркоманнар гаиләсе – Сабонислар яши. Алар күршедәге зур, зиннәтле өйне һәрвакыт күз уңында тота. Шуларның кече малаен энәгә утыртсалар, менә акчаны суырлар иде.* Сәламәт булыйк! **Энәгә утыру** Наркотиклар кабул итә башлау, наркоманга әйләнү. *Малаең яки кызың энәгә утырса, байлыгың оныкларыңа калу түгел, ничек итеп соңгы ыштаныңны салганыңны үзең дә сизми калырсың әле, туган.* З.Хөснияр. *СПИД белән күбрәк наркоманнар зарарлана, дип әйтәләр. Альбертның энәгә утырганы юк әле үзе. Әмма энәгә утырган наркоман кызлар белән йоклаганы бар.* З.Мәхмүди. **Энәдән (генә) төшкән** *к.* **энәдән (генә) чыккан**. **Энәдән (генә) чыккан** Өр-яңа, бөтенләй киелмәгән, әле генә тегелгән (кием). **Энәдән дөя ясау** Эшне, вакыйганы чамасыз арттырып сөйләү; күпертү. *Югыйсә үзегез беләсез биредә эшләүчеләрне... Күбесе энәдән дөя ясарга ярата.* Ф.Зыятдинов. *Хәсән белән Инсаф --- бер-берсенең эшеннән гаеп эзлиләр, энәдән дөя ясап маташалар, форсат чыккан саен үз абруйларын күтәреп калырга тырышалар иде.* Ф.Сафин. **Энәдән җебенә кадәр** Булган берсен, барысын да. *Энәдән җебенә кадәр сатып эчтең инде, Сәрия, алмашка сыңар күлмәгем дә калмады.* Н.Гыйматдинова. **Энә кадәр** *к.* **энә очы кадәр**. *Арада энә кадәр гаебе өчен дөя кадәр җәза алып, эчтән сызып йөрүчеләр дә, судан коры диярлек чыгып, төрмәне ял йорты урынына күрүчеләр дә җитәрлек, зона эченә керсәң.* Н.Әхмәдиев. **Энә калынлыгы** Бик юка, үтә юка. *Келәм өстендә, мыр-мыр килеп, күзен энә калынлыгы гына ачып-йомып, таралып яткан песи дә ачуны гына кабарта, теге хис-*

*не генә күпертә.* Ф.Җамалетдинова. **Энә кебек ялангач** Үтә ярлы, фәкыйрь. **Энә күзе аша уздыру** *к.* **энә күзеннән үткәрү**. *Кешене энә күзе аша уздырып тикшергән күрше карчыгы: – Нәҗибулла абзыйның йөрешләре кыек-мыек, – диде.* Н.Гыйматдинова. **Энә күзе аша үткәрү** *к.* **энә күзеннән үткәрү**. **Энә күзе аша үтү** 1) Бик җентекле тикшерүдән үтү. *Бик нечкәләп карап тирәякка, Энә күзе аша үткән чакта «Алай икән-н...» дигән уй кала.* Г.Афзал; 2) Мөмкин булмаган, бик кыен булган нәрсәне булдыру. *Укыгыз һәм, әйтергә кирәк, энә күзеннән үтеп булса да кереп, кулакның яшерен икмәген таптыртыгыз.* Ф.Хөсни. **Энә күзе зурлыгы** *к.* **энә күзе кебек (хәтле, чаклы, шикелле)**. *Ә хәзер Британиянең нәрсәсе калды – Сингапур да энә күзе зурлыгы Гибралтар.* М.Юныс. **Энә күзе кебек (хәтле, чаклы, шикелле)** Бик кечкенә, вак. *Энә күзе хәтле бәла, зурая-зурая, дөя хәтле хәсрәткә әверелә икән: Билалетдин чиреннән мантымыйча үлеп китте.* Н.Гыйматдинова. *Ә күңелдә бушлык, ялгызлык дәвам итте. Шул буш һәм караңгы төннәрнең чиксез караңгылыгында анда-санда энә күзе кебек өмет яктысы балкып китте.* Э.Шәрифуллина. **Энә күзеннән дөя күрү** *к.* **энәдән дөя ясау**. **Энә күзеннән кичерү (үткәзү)** *к.* **энә күзеннән үткәрү**. *Мин, агай-эне, мондагы атларны энә күзеннән үткәзеп чыктым инде.* К.Тимбикова. **Энә күзеннән төшкән кебек** Аз гына; күренер-күренмәс кенә. *Әнә еракта авыл утлары энә күзеннән төшкән кебек кенә чагылып алды.* М.Галиев. **Энә күзеннән үтәрлек** Нечкә билле, бик сылу. **Энә күзеннән үткәрү** Бик җентекләп, нечкәләп тикшерү. *Бик астындагы тоткыннарга ике-өч көн ашарга бирмиләр, сусыз тоталар, энә күзеннән үткәреп, кемнең ни дәрәҗәдә гаепле икәнен якынча ачыклагач, этап арты этапка куалар.* А.Гыйләҗев. *Энә күзеннән үткәрмичә үзенең эшенә сине алыр ди, бар!* З.Фәтхетдинов. **Энәләрен калкыту** *к.* **энәләрен тырпайту**. *– Нигә җыелган бу халык? Аю биетәләр мәллә монда? – ди ул, беренче сүзе белән үк керпедәй энәләрен калкытып.* Ф.Хөсни. **Энәләрен тырпайту** 1) Киреләнү, үзсүзләнү. *Агент аның сөйләгәннәрен берәмберәм ялганга чыгарып битенә бәрер дигән шик һаман аны сагайта һәм аның җаенарак ятарга, энәләрен тырпайтмаска мәҗбүр итә иде.* Х.Камалов. *Күралмыйм мин бу тормышны, яратмыйм. Шуңа күрә энәләрем гел тырпайган килеш минем.* З.Хөснияр; 2) Ачулану. *Рәмисәнең җавабы әзер. Ул чакта, мине ташларсың, дип курка идем... Хәзер нигә энәләреңне тырпайтасың?..* Х.Камалов. *Мамак бу лейтенантның тылдагы урыны өчен кемнәр алдында тәлинкә тотканын --- белә иде. Энәләре шуңа тырпайган иде.* Р.Фәтхрахманов. **Энәне бүрәнә итү** *к.* **энәдән дөя ясау**. **Энә очы кадәр** Бик кечкенә; аз гына. *--- әгәр Шакирының энә очы кадәр генә хыянәтен сизеп калса, кечкенә усал ерткычтай, нинди ләззәт белән үч аласын уйлап хыяллана.* Ә.Еники. *--- Әлтәфинең энә очы кадәр дә гаебе юк иде.* М.Мәһдиев. **Энә очы кадәрле (хәтле, чаклы)** *к.* **энә очы кадәр**. *Малайның җаны-тәне бөрешкәндәй булды, гүяки сакланырга теләгәндәй, күз бәбәкләре, кысылып, энә очы хәтле генә булып калды.* М.Маликова. *Син, тавык төсле, сукмактагы энә очы кадәрле әйберне дә чүпләрсең, дигән идем – кара, дөрес булды.* Н.Гыйматдинова. **Энә очына элердәй** *к.* **энә очы кадәр**. *Бу кадәр оятсызлыкка нәрсә дип җавап бирәсең! Энә очына элердәй хыянәтең булса иде, ичмасам.* Н.Әхмәдиев. **Энә өстендә бию** Бик ашыгыч эшләү, көч-хәл белән генә җитешү. *Мин, йөрәгемнән кан тамызатамыза, энә өстендә бии идем. Мәслихнең төрттерүләре ярамны тагын да тирәнәйтә иде.* Н.Гыйматдинова. **Энә өстендә тору** *к.* **энә өстендә (очында) утыру**. *– Яхшы, яхшы, – диде ул, аларны хуплап, – фрицлардан ничек саклап кала алдыгыз? – Энә өстендә торылды инде... – дип, карчык агарган чәчләрен чигәсеннән сыпырды.* Х.Камалов. **Энә өстендә (очында) утыру** 1) Уңайсызлану, уңайсыз хәлдә калу; оялу. *Мине чыгырдан ук чыгарып аткач, тагын тыпырчына башладым. Энә өстендә утырам кебек. Ләкин аңларга тырышам.* Ә.Баян. *Бакый, эчтән тынычлана башласа да, әлегә Шамкаевның төп сүзгә күчмәвен сизенә, һаман энәләр өстендә утыра иде.* М.Галиев; 2) Борчылу, тынычсызлану. *Укытучыбыз Тәнзилә апа өй эшләрен тикшергәндә, мин энәләр өстендә утырдым кебек.* Р.Низамиев. *Менә алып китәләр, менә алып китәләр дип, атна буе энә өстендә яшәгәндәй яшәдем.* М.Әмирханов; 3) Китәргә теләп тә китә алмыйча утыру, түземсезләнү. *Рәйхана кызы турындагы борчулы хәбәрен Мансурга әйткәч, егет бөтенләй телдән язды, чәй янында энә өстендә утыргандай утырды.* А.Расих. *Ә мин энә өстендә утыргандай булсам да, җыелышның ахырын көтәргә мәҗбүрмен.* Л.Ихсанова. **Энәсеннән алып җебенә кадәр** *к.* **энәсеннән җебенә кадәр**. *Безнең «эш» бер атнага диярлек сузылды. Башта экипаж әгъзаларының һәркайсын аерым-аерым чакырып, энәсеннән алып җебенә кадәр төпчен-деләр.* Р.Ибраһимов. **Энәсеннән җебенә кадәр (хәтле, чаклы, -чә)** 1) Нечкәләп, җентекләп, башыннан алып ахырына кадәр, бернәрсәне дә калдырмыйча. *Мин алып килгән җыр текстын энәсеннән җебенә кадәр тикшерә торгач, шактый үзгәрттек ---.* Ә.Рәшитов. *Фаҗигалы үлеменә 150 ел тулу датасы бөтен дөнья тарафыннан билгеләнә, иҗатына кагылышлы мәсьәләләр энәсеннән җебенәчә яңадан өйрәнелә ---.* Р.Гатауллин. *Шуннан Илүзә көнозын йөреп күргән-белгәнен энәсеннән җебенә чаклы сөйләп китәр иде.* А.Вергазов; 2) Бөтенләй, тулысынча (яңгырдан һ.б.ш.дан өс-баш чылану тур.). *Энәбездән җебебезгә чаклы чылатты. Чиләкләп бәрә.* С.Җәлал. **Энә сыярлык** Кечкенә генә, бик кечкенә. *Келәттә энә сыярлык та ярык юк, түшәмен сүттем аптырагач.* Н.Гыйматдинова. **Энә табарлык** Бик якты. *Йөзен ачып җибәрүгә, бөтен өй эче энә табарлык булып яктырды, һәм, дөньяны җимергән шикелле, каты итеп күк күкрәп җибәрде.* М.Әмир. *Ай бөтен урамны, күк йөзен, өй түбәләрен ялт итеп балкыткан, җирдән энә табарлык иде.* Ф.Садриев. **Энә тишегеннән үтә торган** Үткен, елгыр кеше турында. *Башыңны ашаячак әле ул малай синең. Авызын ачып йөрми ул синең кебек. Энә тишегеннән үтә торган. Бөтенесен җайлап, көйләп өлгергәндер.* Т.Миңнуллин. **Энә төртерлек (төшәрлек, чәнчерлек) тә урын булмау** Гадәттән тыш тыгызлык, кысанлык турында. *--- вокзал эче төенле-капчыклы халык белән шыгрым тулы: энә төшәр урын да юк.* Ә.Еники. *Клуб эчендә энә төшәрлек урын булмаса да, бу әле – килгән халыкның өчтән бере генә.* Н.Әхмәдиев. **Энә төртерлек (төшәрлек, чәнчерлек) тә урын калмау** *к.* **энә төртерлек (төшәрлек, чәнчерлек) тә урын булмау**. *Вагон эчендә энә төр-*

*терлек тә урын калмагач кына --- бульдозерчы күкрәк кесәсеннән каралып беткән путёвкасын тартып чыгарды ---.* А.Гыйләҗев. **Энә түгел** «Кечкенә әйбер түгел, югалса да табылыр» мәгънәсендә кулланыла. *Гаскәр энә түгел, күренә.* Ш.Рәкыйпов. *Ничек болай, дип баш вата Зәй, кеше энә түгел бит төшеп югалырга? Менә нинди әйбәт кеше кинәт юк булды.* Х.Камалов. **Энә тыгарлык (ташларлык) түгел** Бик тыгыз, еш нәрсәләр турында. **Энә үтмәслек** *к.* **энә тыгарлык (ташларлык) түгел**. *Карчык килеп җиткәндә генә, егет таракны алып ыргыта, шуннан энә дә үтмәслек урман була.* Әкият. **Энә чаклы** *к.* **энә очы кадәр**. *Күңелләрдә кинәләр юк энә чаклы.* Г.Афзал

**ЭНӘБАЛЫК** *и. зоол.* Энәлеләр семьялыгыннан озын нечкә балык. *Еланбалык, энәбалык, сарган, сельдь короле тар балыклардан санала.* Биология. *Татарстан сулыкларында элек очрамаган яңа төрләр күренә башлады. Болар – күл чабагы, чуарбалык, елга еланбалыгы, тюлька, энәбалык.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**ЭНӘ-ҖЕП** *җый. и.* Энә һәм җепләр. *Зөбәйдә энә-җеп алып оекбаш ямарга керешә.* М.Хәсәнов. *Беренче дәресләрдә Наилә Хәбировна энә-җеп һәм уймак белән ничек эш итәргә кирәклеген өйрәтте.* А.Вергазов

◊ **Энәдән-җептән** Баштанаяк яңа киемнән, гел яңа киемнән генә. *Батырайган егет – өс-баш энәдән-җептән: күк костюм-чалбар, аякта елтыр штиблет, --- йон костюмына төрдәш галстугына алтын булавка атландырган.* А.Гыйләҗев. *Кичкә таба Алмас, энәдән-җептән киенеп, каядыр китәргә җыена башлады.* Р.Мулланурова. **Энәдән-җептән (генә) төшкән** *к.* **энәдән (генә) чыккан**. *Әлбәттә, энәдән-җептән генә төшкән, кызлар куа торган кием түгел иде аның өстендә ---.* Р.Кәрами. **Энәдән-җептән (генә) чыккан** *к.* **энәдән (генә) чыккан**. *[Степан Зайцевның] Өстендәге киеме энәдән-җептән генә чыккан дигәндәй, өр-яңа, һәммәсе – иң югары сорт.* М.Насыйбуллин. *--- администратор картка сүз юктан сүз булсын өчен генә сорау бирде: – Бүтән номерларны да шулай, энә-җептән чыккан кебек итеп, өр-яңадан агартып торасызмы?* З.Фәтхетдинов. **Энә-җептән чыккан (төшкән)** *к.* **энәдән (генә) чыккан**. *--- пульт артына баскан дирижёрның кара фрагы да, яктылык сибеп торган ак яка-манжетлары да әле энә-җептән төшкән, ә үзе яңа гына ясалган курчак төсле сөйкемле --- иде.* М.Маликова. **Энә-җептән уздыру** *к.* **энә күзеннән үткәрү**. *Мондый әрләүләргә, Кәримәкәйне энә-җептән уздыруларга Вәли әллә кайчаннан күнегеп беткән иде.* Ф.Яхин

**ЭНӘ́ КАРАГЫ** *и. зоол.* Энә караклары семьялыгыннан озын нечкә гәүдәле, очканда үзенчәлекле тавыш чыгара торган, ике пар үтәкүренмәле канатлы ерткыч бөҗәк; *русчасы*: **стрекоза**. *[Сәвиләг]: Быел энә карагын күрдеңме? «Энә карагы – энә урлый» дип, безне бәләкәй чакта әбиләр алдый иде.* Н.Гыйматдинова. *--- энә караклары исә бер урында асылынып калгандай хәрәкәтсез торалар да ялт итеп кенә икенче урынга күчәләр.* Р.Фәизов

**ЭНӘ́ КАРАГЫ ҮЛӘНЕ** *и. бот.* *к.* **торнабаш**

**ЭНӘКОРСАК** *и. зоол.* Энәкорсакчалар семьялыгына караган, Африка, Көньяк Азия һәм Океания сулыкларында тереклек иткән балык; *русчасы:* **иглобрюх**. *Энәкорсак дип тә аталып йөртүче бу балыкта, цианидтан да көчлерәк, тетродотоксин дигән агу бар, ди.* Ватаным Татарстан

**ЭНӘКОРСА́КСЫМАННАР** *и. зоол. күпл.* Казналыклары яхшы үсеш алган, тәннәре энәләр, чәнечкеләр, сөякле пластинкалар белән капланган балыклар отряды; *русчасы*: **иглобрюхообразные**

**ЭНӘЛӘНҮ** *ф.* 1) Энә формасына керү, энә рәвеше алу. *Кар кристаллары энәләнү*

2) Энәләрен кабарту. *Дикобраз энәләнү*

3) *күч.* Киреләнү; ачулану; энәләрне тырпайту. *Ачуым чыкты. Мин дә керпе шикелле энәләндем.* Н.Дәүли. *Бергә чакта ни дип энәләнәбез соң без, ни дип бер-беребезнең күңел түгәрәклеге турында кирәгенчә уйламыйбыз?* Б.Камалов

**ЭНӘЛЕ** *с.* 1) Энәсе (*1–5 мәгъ.*) яки шуңа охшаш детале булган. *Әнисе улы чистарткан мамыкны ике рәтле, биекозын энәле куркыныч тарак аша тарап үткәрә ---.* Р.Мирхәйдәров. *Берничә рәт тимер энәле тарагычлар белән таралгач, сүс озыная, тәрәш хәленә керә.* Дөньяда ниләр бар?

2) Ылыслы. *Юл буенда озын энәле чыршылар үсә*

3) Чәнечкеле (үсемлекләр тур.). *--- күгән агачларының яфраклары күренми, озын энәле ботакларын күмгәк җимеш сырып алган ---.* Р.Хәбибуллина. *Өй артында бакча гөлләре, Кайберләре була энәле.* Ч.Мусин

4) Чәнчә торган үсентесе, энәсе (*8 мәгъ.*) булган (хайваннар тур.). *Кенәз кызы Керпене үбүгә, аның энәле тиресе шуышып төшеп, каршысында баһадирдай яп-яшь егет пәйда булган.* Әкият

5) *күч.* Усал, зәһәр, яман; усаллыкны чагылдырган. *Озак карап торды немец өч солдатка, бигрәк тә Василий чыраена «мәхәббәте» төште булса кирәк, энәле күзләрен озаклап аңа текәде.* Ә.Еники

6) *күч.* Төртмәле. *Син хәзерге кебек энәле сораулар бирми идең ул чагында.* Ф.Хөсни. *Варис әнисенең энәле сүзләрен ошатмавын сиздерде.* Б.Камалов

**ЭНӘ́ТӘНЛЕЛӘР** *и. зоол. күпл.* *к.* **энәтирелеләр**. *Энәтәнлеләрнең хәрәкәт итү аппараты иң камил гидродинамик җайланмалардан санала ---.* Кызыклы физиология

**ЭНӘ́ТИРЕЛЕЛӘР** *и. зоол. күпл.* Тиреләре өске яктан тырпаеп торган известь энәләр белән капланган, йолдызсыман, шарсыман, дисксыман h.б. формадагы, су төбендә яши торган умырткасыз хайваннар тибы; *русчасы:* **иглокожие**. *Энәтирелеләрдә, кайбер суалчаннарда һәм буынтыгаяклыларда аталанмый калган күкәйләр, аталанган күкәйләр шикелле үк, бүленә башларга мөмкин.* Кызыклы физиология. *Умырткасызларга суалчаннар, моллюсклар, энәтирелеләр --- һәм хайваннарның кайбер башка төркемнәре керә.* Табигать белеме

**ЭНӘ́-ТОТАНАК** *и. к.* **элә-танак**. *Нәҗип, кулындагы мөлдерәмә тулы чәркәне болгап, тост әйтергә маташты, сүзенең энә-тотанагы булмады.* А.Гыйләҗев

**ЭНГАРМО́НИЗМ** *и. гр. муз.* Язылышта төрле булган аваз, интервал, аккордларның югарылыкта туры килүе, аһәңләшү күренеше (мәс., *до-диез – ребемоль*)

**ЭНДӘ́Ш СҮЗ** *и. грам.* Сөйләмдә төбәлеп әйтелгән затны, предметны белдерә торган сүз яки сүзтезмә. *Беркөнне мәктәптә «Эндәш сүз» темасы буенча дәрес биргәндә, Каюмда кисәк кенә шундый фикер туды ----.* М.Мәһдиев. *Хилаф Гәрдани Төркиядә ун еллап торды да «Төрки телләрдә җөмлә башында килгән эндәш сүз артыннан куелган өтернең йөкле хатыннарга уңай тәэсире» дигән темага диссертация яклады...* Р.Батулла

**ЭНДӘШҮ** *ф.* 1) Кемгә яки нәрсәгә дә булса берәр сүз, сорау белән мөрәҗәгать итү, дәшү. *Рәүфәгә сүз кушкан чакларда инде ул аңа кешегә эндәшкән шикелле эндәшми, ә ничектер мыгырдана, коры һәм бик тупас итеп эндәшә.* А.Шамов. *Авыр хезмәттән бүртеп тамырланган кулларын алга сузып, кыюсыз гына: – Зәйнәп... кызым... кайттыгызмы?! – дип эндәште.* Х.Ибраһим

2) Гомумән, сүз әйтү, сөйләшә башлау, сөйләшү. *Кешеләр башта эндәшмичә генә ашадылар.* Ш.Камал. *Ул көн буе бер сүз эндәшмәде. Ә төннәрен калып ялгызы, Ак кәгазьгә тутырып хатлар язды, Калыкканчы Чулпан йолдызы.* Ш.Маннур

3) Җавап бирү. *Дөрес, әти-әнисеннән, абыйсы Мисбахтан аңа хатлар килгәли, ә Миңнурый нигәдер бөтенләй эндәшми.* Г.Әпсәләмов. *Җәмилә: – Син мине, бу нинди сәер, дип уйлыйсыңдыр инде, әйеме, юләр, дисеңме? – Җантимер эндәшмәде.* Ф.Яхин

**Эндәшеп алу** *к.* **эндәшеп кую**. *Кулларын күкрәк тирәсенә куеп, кычкырып кемгәдер эндәшеп алды.* Ф.Сафин

**Эндәшеп карау** Сынау, тикшерү, белү максаты белән эндәшү. *Бу дөньяда очраклы бернәрсә дә юк бит, бәлки, тәвәккәлләп, эндәшеп карарга кирәктер?* Ф.Бәйрәмова. *Эндәшеп тә карады аңа хатын: «Зинһар, мине әзәрлекләмә, күршекәем! Мин болай да тере мәет», – диде.* Н.Гыйматдинова

**Эндәшеп кую** Бер тапкыр эндәшү. *Картның җан газапларын күреп, зиратта эшләүчеләрнең берсе аңа татарча эндәшеп куйды: – Син алай ук борчылма, абзый кеше, – диде ул.* Ф.Бәйрәмова. *– Тик кенә тор, – дип кырыс кына эндәшеп куйды Искәндәр.* Д.Бүләков

**Эндәшеп тору** Әледән-әле, даими эндәшү; әле, хәзерге вакытта эндәшү. *Хәлбуки аның алдында чиге юк киң ачыклык, ямьле зәңгәр күк, җем-җем килгән якты йолдызлар, ни кадәр тау, урман вә сулар – һәммәсе «бездәге серләрне бел» дип, аңар мәгънәви телләре белән эндәшеп торалар.* Г.Буби

**ЭНДЕМИ́Я** *и. гр. мед.* Билгеле урында шул урынның географик, физик һ.б.ш. үзенчәлекләре аркасында, шулар белән бәйле авырулар барлыкка килү күренеше

**ЭНДО-** *и. гр.* Кушма сүзләрдә «эчке» мәгънәсен белдерә торган беренче компонент (мәс., *эндоген, эндодерма*)

**ЭНДОГАМ** *с.* Билгеле бер социаль катлау (нәсел, ыру, каста) эчендә генә өйләнешү йоласына буйсынган. *--- мөселманнар аерым авылларда, кайбер очракларда руслар белән бергә яшәгәннәр. Алар хәтта үз эчләрендә генә никахлашып, аерым бер эндогам берәмлеккә әйләнеп, этник яктан изоляцияләнгәннәр.* Д.Исхаков

**ЭНДОГА́МИЯ** *и. гр.* Үз нәселеннән, ыруыннан, кастасыннан яки социаль катлавыннан гына өйләнү йоласы. *Кабиләләр һәм катламнар эчендә гаилә кору – өйләнү мәсьәләсендә эндогамия һәм гипергамия таралган*

**ЭНДОГЕН** *с. кит.* Эчке сәбәпләр аркасында барлыкка килә торган; эчке сәбәпләр белән аңлатыла торган. *Организмнарның үзгәрешендә бигрәк тә җирнең эндоген көче зур роль уйнаган.* А.Фәткуллин. *Прогрессив җәмәгатьчелек, бер генә халыкның да, бер генә мәдәниятнең дә җир йөзендә артык булмавына, этносларның бер-берсен тулыландыруына, кешелекнең эндоген потенциалын тәшкил итүенә инанган хәлдә, вак телләрне саклап калу чараларын эзли.* Фән һәм тел

**ЭНДОДЕ́РМА** *и. гр. бот.* Үсемлекләрнең сабакларында һәм тамырларында үткәрә торган тукымаларны әйләндереп алган эчке күзәнәкләр катлавы

**ЭНДОКАРД** *и. гр. анат.* Йөрәкне эчке яктан уратып алган сүрү, юка пәрдә; йөрәкнең эчке катлавы. *Ревматизм йөрәкнең бөтен җирен – мускулын (миокардны), тышкы сүрүен (перикардны), эчке сүрүен (эндокардны) һәм клапаннарын зарарлый.* Юлдаш

**ЭНДОКАРДИТ** *и. гр. мед.* Эндокардның ялкынсынуы (еш кына йөрәк клапаннары зарарлануына китерә). *Ангинаның хроник тонзиллитка күчүе, соңгысының буыннарда ревматизм, йөрәктә эндокардит, бөерләрдә нефрит --- тудыруы ихтимал.* Ш.Хөсәенов. *Хастаханәдә аңа бактериаль эндокардит дигән куркыныч диагноз куялар.* Ватаным Татарстан

**ЭНДОКРИН** *с. физиол.* Эчке секреция бизләре системасы һәм шуның эшчәнлеге белән бәйле булган. *Экзема нервлар, ягъни эндокрин системаның какшавыннан яисә дәвамлы авырулар нәтиҗәсендә барлыкка килә.* Сәламәт булыйк! *Башка эндокрин авырулар ачыкланмады.* Фән һәм тел

**ЭНДОКРИНО́ЛОГ** *и. гр.* Эндокринология белгечлеге буенча табиб. *Вера иренә мондый яңалык әйтте: – Табибта булдым. Ирең башта эндокринологка күренеп карасын --- дип әйтте, – диде.* Я.Шәфыйков. *Энем Фиргать --- – танылган врач. Зур белгеч булып санала. Эндокринолог.* Р.Таҗетдинов

**ЭНДОКРИНОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Медицинаның эчке секреция бизләренең төзелешен һәм функцияләрен, аларның гармоннарын һәм организмга тәэсирен өйрәнә торган тармагы. *Шуңа да шикәр диабеты белән чирләүче йөкле хатын-кызларга ярдәм күрсәтү өчен, медицинаның өч өлкәсе – акушерлык, эндокринология һәм перинатология табиблары берләшергә мәҗбүр.* Сөембикә. *Эндокринология фәнни үзәгенең төрле төбәк белгечләре белән берлектә үткәргән тикшеренүләре шуны күрсәтә: Россиядә йод җитешмәүдән барлыкка килгән авыруларга дучар булмаган бер генә район, шәһәр дә калмаган.* Шәһри Казан

**ЭНДОКРИНОПА́ТИЯ** *и. гр. мед.* Эчке секреция бизләре эшчәнлеге бозылу нәтиҗәсендә барлыкка килгән барлык авыруларның гомуми исеме

**ЭНДОМЕТРИТ** *и. гр. мед.* Аналыкның лайлалы тышчасы ялкынсынуы. *Хроник эндометрит йогышлы микроблар аркасында килеп чыкканга, аны антибиотиклар белән дәвалыйлар.* Сөембикә

**ЭНДОРФИННАР** *и. күпл.* Үзәк нерв системасы эшләп чыгара торган, аминокислота калдыкларыннан гыйбарәт органик матдәләр. *Хәтерлисеңдер, гел стресс хәлендә яшәвемнең фәнни сәбәбен син баш миендә гаҗәеп молекулалар – эндорфиннар җитмәве белән аңлаткан идең?* Ә.Баян. *Ихтыярсыз кыз. Эш юклык, вакыт күплек аркасындамы? Әллә инде, чыннан да, кызның баш миендә эндорфиннар җитмиме?* Ф.Миңнуллин

**ЭНДОСКОП** *и. гр. мед.* Организмдагы эчке куышлыкларны (мәс., корсак, плевраль һ.б.) тикшерү һәм дәвалау приборы. *Шуңа да дәвалау оешмаларында рентген, томограф, эндоскоп ише җиһазлар булдырырга кирәк.* Ватаным Татарстан

**ЭНДОСКО́ПИК** *с.* Эндоскопия белән бәйле, эндоскоп ярдәмендә башкарыла торган. *Эндоскопик операция ясаганда корсакта кечкенә генә тишек тишелә һәм шул тишек аша --- авырткан урынга операция ясала.* Ватаным Татарстан. *Флюорография, ЭКГ, УЗИ, ашказаны-эчәк трактын эндоскопик ысул белән тикшерү каралган.* Йолдыз

**ЭНДОСКОПИ́Я** *и. гр. мед.* Организмдагы эчке куышлыкларны эндоскоп белән карау, тикшерү ысулы. *Аналыктагы миоманы гадәти тикшерү вакытында яисә ультратавыш, рентген, эндоскопия ысулы белән ачыкларга була.* Мирас. *Нәсел калдыруга сәләтсез парларны тикшергәндә --- аналыкка эндоскопия ярдәмендә видеотикшерү үткәрәбез.* Сәламәт булыйк!

**ЭНДОТЕРМИК** *с. хим.* Җылылык йотылу белән бәйле булган. *Энергия йотылса, реакция эндотермик реакция дип атала.* Физика. *Эндотермик процесслар термограммада батынкы, ә экзотермик процесслар кабарынкы булып сурәтләнә.* Төзү материаллары

**ЭНДОТЕРМИ́Я** *и. гр.* 1) Түбән температура шартларында тере организмнарның, үзләренең эчке мөмкинлекләре исәбенә, тән җылылыгын югары тотуга сәләтлелеге

2) Югары ешлыклы электр токлары белән организм тукымаларын җылытудан гыйбарәт дәвалау ысулы

**ЭНДОТОКСИН** *и. гр.* Микроблар таркалганда, һәлак булганда барлыкка килә торган токсин (агу). *Вируслар, таркалганда, иммун системасы эшчәнлеген тоткарлаучы эндотоксиннар барлыкка китерә.* Ирек мәйданы

**ЭНДШПИЛЬ** *и. нем. спорт* Шахмат һәм шашка уеннарының соңгы, төгәлләнү стадиясе

**ЭНЕ** *и.* 1) Үзеңнән кече ир туган; энекәш. *Иң ахырда Вахитның энесе Сабир төшендә абзасын күрүен, тик ничек күрү рәвешен онытканын сөйләде.* М.Гафури. *Алдагы йөктә, Җәүдәтнең кечкенә энесен көзге җилдән яшереп, арба уртасына әнисе утырган.* Г.Әпсәләмов

2) Яшькә кече булган ир заты; энекәш. *Бу егет миңа абый түгел, эне генә*

**ЭНЕКӘШ** *и.* 1) *ирк. к.* **эне**. *Мондый хатларны минем энекәш буш вакытларда дистәләп яза иде.* А.Шамов. *Николай Иванович үзе турында гына кайгырта торган тар кеше булмады, ул үзе артыннан энекәшләрен тартты ---.* Т.Галиуллин

2) *к.* **энем** (*2 мәгъ.*). *Ә мин, энекәш, шулай да кул куя алмыйм бу эшкә, юк әле.* Г.Гобәй. *Сезгә, Газиз энекәш, карт геолог белән бәхәс ачканчы, күбрәк әнә кулыгыздагы нәрсә белән шөгыльләнергә кирәк.* А.Әхмәт

**ЭНЕМ** *и. тарт. форм.* 1) *к.* **эне** (*1 мәгъ*). *Әнкәй ундүртәр сәгать эшләп эттәй арып кайта, ә энем Камәретдин аны: «Әнсәү, мәми, әнсәү, мәми», – дип елап каршы ала.* А.Әхмәт. *Ике елдан соң, унберенче бала булып, Илдархан исемле энем дөньяга килә.* Ә.Еники

2) Үзеңнән кечерәк яшьтәге ир затына мөрәҗәгать итеп әйтелә. *[Җамали] Без үзебез, энем, көн-төн хөкүмәт өчен тырышып йөрүче бер бәндә инде.* А.Әхмәт. *Кара әле, кем, энем Зәйни, калдырып тор әле беразга шушы гармуныңны.* Ф.Бурнаш

3) Кемне дә булса кимсетебрәк мөрәҗәгать иткәндә кулланыла. *[Сафый:] Башың яшь әле, энем, синең!* Ф.Әмирхан

**ЭНЕОЛИТ** *и. лат.-гр. археол.* Неолиттан бронза гасырына күчү чоры; халколит гасыры (таш кораллар куллану белән беррәттән беренче тапкыр бакыр кораллар барлыкка килгән чор). *Татарстан территориясендә һәм аңа якын Урта Идел буе районнарында энеолит чорында волосово археологик культурасына караган кабиләләр яшәгән.* Татарстан тарихы. *--- металларны үзләштерүдән башланган чор (металлдан эшләнгән беренче хезмәт кораллары б.э.к. IV–III меңьеллыкларда гына киң тарала) энеолит (бакыр-таш гасыры) дип атала.* Бөтендөнья тарихы

**ЭНЕРГЕТИЗМ** *и. гр. филос.* XIX гасыр ахырында барлыкка килгән, эмпириокритицизмга якын идеалистик фәлсәфи концепция. *Үзенең 1910 елларда басылып чыккан --- хезмәтләрендә, энергетизм карашларына таянып, ул материализм һәм атеизмны юкка чыгарырга алына.* Я.Абдуллин

**ЭНЕРГЕ́ТИК** I *и. рус* 1) Энергетика белгече, энергетика сәнәгате хезмәткәре. *Идарәнең энергетигы --- Мөнип Сәлахов килгәндә, Илфир багана башында алюмин чыбыкны тәтәйгә беркетеп маташа иде.* Р.Кәрами. *Аның [академиянең] составына шул ук химиклар, физиклар, математиклар, энергетиклар, медиклар һәм башка шундый төгәл фәннәр вәкилләре кереп тулды.* Т.Галиуллин

2) Энергетизм тарафдары

**ЭНЕРГЕ́ТИК** II *с.* 1) Энергетика (*1 мәгъ.*) белән бәйле, энергия җитештерүгә һәм файдалануга мөнәсәбәтле. *Ә чимал һәм энергетик ресурсларны экономияләү мәсьәләсе ничегрәк тора?* М.Сәлим. *Татарстанда табигый энергетик чыганаклар да бар.* Ф.Зариф

2) Энергиянең (*1 мәгъ.*) барлык төрләрен эшләп чыгару һәм куллануга бәйләнешле. *Очучы бал корты зур йөк белән очканда, энергетик материалны аз сарыф итә.* Татарстан балы. *Майлар организмда шулай ук пластик һәм энергетик роль уйный.* Сәламәтлек нигезләре

**ЭНЕРГЕ́ТИК** III *и.* **1.** Үзәк нерв системасына тонус бирә, хәл кертә, йокыны ача, эшкә сәләтлелекне арттыра дип исәпләнгән, составында кофеин һ.б. матдәләр булган газлы эчемлек. *Энергетиклар сатуда юк, Татарстанда аз алкогольле спиртлы эчемлекләр – энергетикларны сатуны тыйганнар.* Шәһри Казан

**2.** *с. мәгъ.* Шундый үзлекләргә ия. *Күреп торабыз: Русиядә, бигрәк тә шәһәрләребездә, чипсы, кока-кола һәм энергетик эчемлекләр ашап-эчеп тә менә дигән итеп яшәргә була, дип ышанган буын үсте.* Мәдәни җомга. *Энергетик эчемлекләр бигрәк тә үсмерләр организмына начар тәэсир итә.* Кызыл таң

**ЭНЕРГЕ́ТИКА** *и. гр.* 1) Энергия ресурсларын үзләштерү, эшкәртү, үзгәртү, тапшыру, файдалану процессларын өйрәнә торган фән. *– Белә ул, белә, – дип каршы төште энергетика институты студенты Наташа Молчанова.* М.Насыйбуллин. *Шәүкәт энергетика институтының хәзерлек группасына урнашты.* Җ.Фәйзи

2) Халык хуҗалыгының төрле энергия эшләп чыгару, аннан файдалану һ.б.ш. белән шөгыльләнә торган тармагы. *Һиндстанда кара һәм төсле металлургия, энергетика, нефть химиясе, электроника, суднолар төзү буенча зур мөмкинлекләр ачылды ---.* М.Мәһдиев. *Энергетика иң мөһим тармак хәзер. Кем шәм яктысында яшәргә риза? Беркем дә...* Р.Зәйдулла

3) Физиканың энергия үзлекләрен өйрәнә торган бүлеге

4) *филос. к.* **энергетизм**

5) Парапсихологиядә уңай яки тискәре үзлекле рухи көч, энергия. *Әгәр кешенең эчке дөньясы, уй-фикерләре уңай энергетикадан гына торса, җир йөзендә авыручылар булмас иде.* Т.Шәрифуллина. *Һәр сүзнең үзенең энергетикасы бар.* М.Сәлимҗанов. *Ләкин кызыгы шунда: Нурихан абый үзе булмаса да, аның рухи энергетикасы Дәрвишләр бистәсеннән үк сизелеп, тоелып тора иде.* Б.Рәхимова

**ЭНЕ́РГИЯ** *и. гр.* 1) Материянең төп сыйфатларыннан берсе, хәрәкәтнең гомуми үлчәве, материя хәрәкәте запасы (механик, җылылык, электромагнит, химик, гравитацион, атом-төш һ.б. формасында). *Энергия саклану законын, чынбарлыктан чыгып, энергия*

*әверелүе төшенчәсе белән бәйләнештә генә, төп-төгәл итеп тәгъбирләргә мөмкин.* Фән һәм тел. *Җылылык энергиясенең икенче өлеше, механик энергиягә әйләнеп, циклонга коточкыч куәт бирә.* Кызыл таң

2) Шуның махсус җитештерелә һәм хуҗалык максатларында файдаланыла торган төре; электр. --- *хәзер алар [колхозлар] үзләренә кирәкле энергияне дәүләт челтәреннән, югары вольтлы линияләрдән арзан бәягә генә алалар.* Г.Галиев. *Түшәмдәге лампочканы сүндереп куйдым. Энергия әрәм булмасын.* Г.Нәбиуллин

3) Куелган максатка ирешү өчен сарыф ителгән, куелган физик яки рухи көч. *Аның [Сәвиләнең] бар энергиясе уйга җыелгән.* Н.Гыйматдинова. *Энергиягезне төп проблемага сарыф итсәгез икән.* Б.Камалов

4) Кеше характерындагы дәртлелек, тырышлык, активлык

**ЭНЕ́РГИЯЛЕ** *с.* 1) Көчле, гайрәтле; җитез, хәрәкәтчән; энергиясе ташып торган. *Яшь ягыннан да кече түгел, үзе өлкән лейтенант, ротамы, батарея командирымы булган, бик энергияле, тимер егет...* Ш.Маннур

2) Эшлекле, актив, тырыш. *Анда [үзәк лабораториядә] Гәрәй, Василий кебек яшь, энергияле, таләпчән, үткен күзле кешеләр кирәк иде.* А.Гыйләҗев. --- *Марсель Мөслимович югары оешмалар алдында ялкынлы трибун, менә дигән оратор, эрудицияле мужик, энергияле җитәкче даннарын казанырга тырыша, югыйсә ул үзе ике җөмлә дә төзи белми.* Г.Афзал

3) Бик нык тәэсир итә торган, көчле. *Бүгенге яшүсмерләр яңадан кызу хәрәкәтле һәм энергияле бию – рэпка тартыла.* Юлдаш. *Аниматорлар артыннан гади һәм энергияле хәрәкәтләрне кабатлап, «Мин яратам сине, тормыш!» бию флешмобына кушылырга була иде.* Кама ягы

**ЭНЕРГОБЛОК** *и. рус* Электростанциянең электроэнергия җитештерә торган генераторы. *Зәй ГРЭСы һаман камилләшә. Түбән Кама ГЭСының II энергоблогы ток бирә.* М.Әмирханов. *Зәй ГРЭСы энергоблокларын җибәргәч, --- Камада гидроэлектростанция салып, энергия арттыруның кирәге калмый икән, дип уйлады халык.* Я.Шәфыйков

**ЭНЕРГОПО́ЕЗД** *и. рус* Тимер юл платформаларында яисә вагоннарда урнаштырылган күчмә электростанция. *1944 елның җәендә, төзелешне тизләтү өчен, «Томсон» фирмасының 5 МВт куәтле энергопоезды килә.* Татарстан яшьләре

**ЭНЕРГОСИСТЕ́МА** *и. рус* Берничә электростанция, электр челтәрләре һәм электр энергиясеннән файдаланучылар җыелмасы; энергетик система. *Аның бөтен хезмәт юлы диярлек Татарстан энергосистемасына багышланган.* Г.Мөхәмmәтшин. *Су белән тәэмин итү системасының яхшы булуы нәтиҗәсендә, Татарстан Республикасы энергосистемасы ышанычлы һәм нәтиҗәле эшләде.* Ватаным Татарстан

**ЭНЕРГОЦЕХ** *и. рус* Энергия җитештерә торган цех. *Анда селикатныйдан мастер Силантьев белән энергоцехның механигы Газизов утыралар.* Э.Касыймов

**ЭНҖЕ** *и. кыт.* **1.** 1) Кайбер моллюскларның кабырчыгы эченнән табыла торган ак, саргылт, алсу, сирәгрәк кара төсле борчак формасындагы кыйммәтле перламутр матдә. *Шулай итеп, бер бөртек ком аркасында бака кашыгы эчендә энҗе үсә.* А.Муратов. *Хәлифәнең борынгыдан калган хәзинәсендә, бер янчык белән, төнлә дә балкып тора торган гәүһәрләр, берничә бик эре энҗе --- һәм берничә рум якуты бар иде.* Борынгы татар прозасы

2) Шул матдәдән ясалган бизәнү әйбере. *Энҗе дә мәрҗән кызларның кулбавы, Авыр җан сөйгәннәрнең булмавы.* Җыр. *Кызлар кич утыра, киндер җеп эрлиләр, шушы җеп эрли торган кызларның беләгендә, кул чугында энҗе дә мәрҗән.* Р.Батулла

3) *күч.* Үзенең тышкы күренеше, ялтыравы, аклыгы белән энҗегә охшаган, энҗене хәтерләтә торган әйберләр турында. *Үләннәр аксыл энҗе белән капланган, урманнар күкселәнгән, агач төпләренә бозлы сары яфрак түшәлгән ---.* М.Мәһдиев. *Бер малай шәйләнә. Ертык күлмәктән, яланбаш, ялан тәнле. Куллары имәнгә чытырдап ябышкан, күзләреннән энҗе бөртекләре тәгәри.* Н.Хәсәнов

4) *күч.* Үзенең сыйфатлары белән башкалардан аерылып торган, нәрсәнең дә булса иң яхшы бизәге, хәзинәсе саналган әйбер яки зат. *«Иң-иң кирәген – фикереңнең энҗесен яз», – диде.* Ш.Рәкыйпов. *Урта гасыр шигъриятенең энҗеләре*

**2.** *с. мәгъ.* Шул перламутр матдәдән ясалган, шуның белән бизәлгән. --- *ә Рушан исә, кичәге шикелле, янә аның өч рәт итеп тезелгән ясалма энҗе муенсалы нәфис муенын, хатын-кызларга гына хас ымсындыргыч түгәрәк ачык иңнәрен сокланып күзәтә.* Р.Мирхәйдәров. *Мин энҗе алкамны салып, аның [Һайганушның] колакларына тагып куйдым.* Р.-Н.Гүнтәкин

**ЭНҖЕ-ҖӘҮҺӘР** *җый. и.* 1) *к.* **энҗе-мәрҗән**. *Колагыңа – алтын алкалар, муеныңа энҗе-җәүһәрләр тагасың.* И.Юзеев. *О, нинди генә тамашаларны күрмәде ул бу балда! Кыпкызыл постау җәелгән подъезд, балкып торган заллар, --- ак, зәңгәр, кызгылт күлмәкләр киешеп, муеннарына, ялангач кулларына энҗе-җәүһәр таккан ханымнар.* М.Гапаров

2) *күч.* Нәрсәнең дә булса иң югары сыйфатлы, иң матур үрнәкләре, бизәкләре, шедеврлары. *Татар теленең энҗе-җәүһәрләре, Тукай әйткәнчә, Казан арты сөйләшендә.* С.Поварисов. *Ә инде халкыбызның энҗе-җәүһәрләре саналган халык җырлары Мәхмүт Нигъмәтҗановның иҗади эшчәнлегендә төп урыннарның берсен алып тора.* Г.Бәйрәмова

**ЭНҖЕЛӘ́Ү** *ф.* Энҗе белән бизәү. *Ул бүрекнең түбәсен ука белән, энҗеләп, кашлар утыртып чигәләр ---.* К.Насыйри

**ЭНҖЕЛЕ** *с.* Энҗе белән бизәлгән, энҗеләре булган. *Зәңгәр атлас күлмәк кигән, ал алъяпкыч япкан, башларына энҗеле калфак кадаган чибәр яшь хатыннар, кызлар көмеш подностар күтәреп --- йөриләр.* М.Мәһдиев. *[Хәнифә] җете кара чәчен малайларча кыска итеп кистергән, килешеп тора тагын үзенә, колагында энҗеле алтын алкалар.* М.Хәбибуллин

**ЭНҖЕ-МӘРҖӘН** *җый. и.* Энҗеләр һәм мәрҗәннәр; энҗе, мәрҗән һәм башка төрле ташлардан ясалган бизәнү әйберләре. *Бөтен Акланның алтынкөмеше, энҗе-мәрҗәне Карун сараена агылган.* Н.Фәттах. *Аңа зур-зур энҗемәрҗәннәр, кочак-кочак гүзәл чәчәкләр бүләк иткәннәр.* Ф.Яруллин

**ЭНҖЕ́ЧӘЧӘК** *и. бот.* Лаләчәләр семьялыгыннан горизонталь тамырчалы, 2–3 яфраклы, ак чәчәкле үләнчел үсемлек; ландыш. *Мисалга энҗечәчәк – ландышны гына алыйк. Май ае урманнарының таҗы ул энҗечәчәк!* А.Гыйләҗев. *Энҗечәчәк вак кына, Җилләр исә сак кына.* Р.Вәлиева

**ЭНЗИМ** *и. биол., хим.* Фермент. *Гөмбәләрдә кеше организмындагы про-*

*цессларны – азыкның сеңүен, матдәләрнең окисьлашуын тизләтә торган ферментлар – энзимнар бар.* К.Тәхау

**ЭНТЕРИТ** *и. гр. мед.* Нечкә эчәкләрнең лайлалы ярысы ялкынсынуыннан гыйбарәт хроник авыру. *Бәпкә үләне төнәтмәсе энтериттан (эчәклек ялкынсынуы), гастриттан файдалы.* Файдалы киңәшләр

**ЭНТЕРОКОЛИТ** *и. гр. мед.* Берьюлы нечкә һәм юан эчәкләрнең лайлалы тышчалары ялкынсынуыннан гыйбарәт авыру. *Официаль медицинада һәм ветеринариядә чыяна тамырының спиртлы экстракты --- эч китү, энтероколитны дәвалаганда кулланыла.* Юлдаш

**ЭНТО-** *гр.* Кушма сүзләрдә «эчке» дигән мәгънәне белдерә торган беренче компонент (мәс., *энтодерма*)

**ЭНТОДЕ́РМА** *и. гр. биол.* Үсешнең башлангыч стадияләрендә күпкүзәнәкле хайваннар һәм кеше яралгысының эчке катламы. *Кабыкның эчке катламнарын (энтодерманы) шулай ук механик тукыма тәшкил итә.* Ботаника

**ЭНТОМО-** *гр.* Кушма сүзләрнең «бөҗәк» дигән мәгънәне белдерә торган беренче компоненты (мәс., *энтомология, энтомофилия*)

**ЭНТОМО́ЛОГ** *и. рус* Энтомология белгече. *Югыйсә берничә председатель, --- баш агроном, баш энтомолог кебек ирләр иркенләбрәк утырырга да каршы түгелләр иде.* М.Мәһдиев. *Россия энтомологлары коңгызларның егәрен тикшергәннәр.* Кызыклар дөньясында

**ЭНТОМОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Зоологиянең бөҗәкләрне өйрәнә торган тармагы. *--- куылып йөрүләр дә Дешанның --- энтомология, ягъни бөҗәкләр турындагы фәнгә бирелгәнлеген сүндерә алмыйлар.* Кызыклар дөньясында. *Энтомология фәненнән билгеле булганча, бөҗәкләр «нигездә паразитизм һәм тышкы шартлар белән көйләнә торган тормыш дулкыны» белән үрчи.* Фән һәм тел

**ЭНТУЗИАЗМ** *и. гр.* Күңел, рух күтәренкелеге, илһамлану, дәртләнү, нык мавыгу. *Алар үзара ярыша-ярыша, адым саен очрап торган кыенлыкларны җиңә-җиңә, зур энтузиазм белән эшлиләр.* А.Алиш. *Хәзер кешеләрнең иманы үзгәрә торган чак. Гөлзадә ханым күргән энтузиазм юк аларда.* А.Гыйләҗев

**ЭНТУЗИАСТ** *и. гр.* Үз эшенә нык бирелгән, шуңа бөтен көчен бирүче, энтузиазм белән эшләүче кеше. *Минзәлә татар дәүләт драма театры директоры, режиссёры Рафаил Усманов Әстерханда театрны аякка бастыру шөгыле белән йөри. Энтузиастлар бар, хыяллар зур.* Т.Галиуллин. *Камил әфәнде хаҗи да, хафиз да, җырчы да – мәшһүрлекне яратучы һәм энтузиаст бер кеше дә иде.* Г.Баттал

**ЭНЦЕФАЛИТ** *и. гр. мед.* Баш миенең ялкынсынуы белән характерланган авыруларның гомуми атамасы. *Тычкансыман кимерүчеләрдә, йомран һәм бу группаның башка вәкилләрендә чума, энцефалит һ.б. йогышлы авырулар була.* Биология. *Зарарлы талпан кадалып 7–21 көн үткәннән соң, кеше энцефалит белән чирли башлый.* Ватаным Татарстан

**ЭНЦЕФАЛОГРА́ФИЯ** *и. гр. мед.* Баш миен рентгенографик юл белән тикшерү ысулы. *Баланы яман шештән, лейкоздан дәвалау өчен, аның сәламәтлек торышын өйрәнүдән тыш, эхокардиография, эпилепсия өянәкләрен профилактикалау, энцефалография --- һәм башкалар кирәк иде.* Әлмәт таңнары

**ЭНЦЕФАЛОПА́ТИЯ** *и. гр. мед.* Нәселдәнлек, инфекция, агулану, җәрәхәтләнү, гиповитаминоз кебек сәбәпләрдән барлыкка килгән ялкынсынусыз баш мие авыруы. *Энцефалопатия җитди өзлегүгә китерә: көзән җыеру нәтиҗәсендә үлемгә китерергә яисә, үзеннән соң, дәвалап булмый торган эпилептик өянәк барлыкка китерергә яки саңгырау калдырырга мөмкин.* Сәламәт булыйк!

**ЭНЦИКЛОПЕДИЗМ** *и. гр.* Җентекле, күпкырлы белем, фәннең күп өлкәләреннән хәбәрдарлык. *Энциклопедизм күренеше, белгәнебезчә, Ренессанс чоры өчен хас.* Ризаэддин Фәхреддин: мирасы һәм хәзерге заман

**ЭНЦИКЛОПЕ́ДИК** *с.* 1) Энциклопедия рәвешендәге, энциклопедия сыйфатларына ия булган; энциклопедиягә охшаган. *1960 елларда, ул энциклопедик белешмәлеккә багышлап, Англиядә бер гыйльми хезмәтнең нәшер ителүе турында Исмәгыйль ага үзе бер сөйләгән иде.* Л.Хәбибуллин. *Бу бүлек әле хәзер дә, бигрәк тә аспирантлар һәм яшь галимнәр өчен, татар фольклористикасы буенча энциклопедик характердагы мөһим чыганак ролен үтәп килә.* Х.Мәхмүтов

2) Фәннең күп өлкәләре белән таныш, күпьяклы белемгә ия булган. *Аны, төрле тармакларда кылган гамәлләренә, язган китапларына карап, энциклопедик табигатьле галим дип тә атарга мөмкин.* Х.Миңнегулов. *Энциклопедик хәтерле Рәдиф Гаташ шунда ук бу елларның Роберт Әхмәтҗанов шигыреннән икәнен әйтеп бирде.* М.Галиев

**ЭНЦИКЛОПЕДИСТ** *и. гр.* 1) *кит.* Энциклопедик белемнәргә ия, фәннең, белемнең күп тармакларыннан мәгълүматлы, хәбәрдар кеше. *Каюм Насыйри – үз вакыты өчен һәм ул вакыт татар халкы өчен энциклопедист галим.* С.Алишев

2) *тар.* Франциядә XVIII гасыр ахырында Дидро һәм Д'Аламбер тарафыннан нәшер ителә торган «Энциклопедия» тирәсендә берләшкән алдынгы акыл ияләренең бер вәкиле

**ЭНЦИКЛОПЕ́ДИЯ** *и. фр. гр.* Белемнең барлык (универсаль энциклопедия) яки аерым тармакларына (тармак энциклопедиясе) караган аңлатмалы сүзлек формасында төзелгән фәнни яки фәнни-популяр белешмәлек-кулланма. *Дәфтәр, әлбәттә, энциклопедия түгел, Актанышның Мәчти авылы кешеләре ул дәфтәрдән Вәли Шәяхмәтов яки Яруллин Сәләхетдинне эзләмәсләр.* Т.Миңнуллин. *Сундук китапханәгә йөгердем, энциклопедиядән карадым: [Шульгин] 1878 елда туган икән.* М.Мәһдиев

2) *иск.* Берәр фәннең төрле тармаклары буенча системага салынган күзәтү

3) *куч.* Тормышны һәрьяклап, киң яктырта торган сәнгать әсәре. *Укучы Тукай эчке дөньясының энциклопедиясен, бер дә аптырамыйча, бөтен каршылыгы белән укый ала.* Г.Халит

**ЭНЦИКЛОПЕ́ДИЯЧЕ** *и. к.* **энциклопедист** (*1 мәгъ.*). *Мин революциягә чаклы өлгергән шагыйрь идем инде. Мин – галим. Мин – энциклопедияче.* Р.Батулла. *Талантының һәм фәнни-иҗат эшчәнлегенең характеры белән ул [Г.Ибраһимов] – энциклопедияче.* Әдәбият

**ЭҢГЕР** *и.* Кояш батканнан алып төнгә кадәр һәм таң алдыннан кояш чыкканга кадәр була торган ярымкараңгылык; шундый вакыт. *Су өстендә уйнаган вак, язгы гөнаһсыз дулкыннарны басып, Идел өстенә хуш исле эңгер иңә.* А.Гыйләҗев. *Табигатьнең үзендә кичке җылы эңгер куерып килә иде.* А.Вергазов

**ЭҢГЕРЛӘҮ** *ф.* Кояш баеганда яктылык әкренләп кимү, караңгылана төшү яки кояш чыкканда караңгылык сыеклану, әкренләп яктыру; эңгер вакыты җитү. *Зиннур Ширьязданга көн эңгерләнгән чакта килеп керде.* А.Расих. *Урман буйларында күксел төтен, Шунда таба күңел тартыла. Үтә дә*

*көн, эңгерләнә дөнья, Кояш бата таулар артына.* Р.Зарипов

**Эңгерләнә башлау** Эңгерләнү билгеләре барлыкка килү. *Тирә-як эңгерләнә башлады*

**Эңгерләнеп бару** Торган саен эңгерләнү

**Эңгерләнеп калу** Билгеле бер хәлдән, вакыйгадан соң эңгерләнгән хәлгә килү. *Эңгерләнеп калды көн уртасы Тоташ килгән болыт астында.* Г.Ибушев

**Эңгерләнеп тору** Эңгерләнгән хәлдә булу. *Кичке авыл эңгерләнеп тора*

**ЭҢГЕ́Р-МЕҢГЕР** *җый. и.* **1.** *к.* **эңгер**. *Акъярны яңа сауган сөт кебек җылы кичке эңгер-меңгер урый.* Г.Әпсәләмов. *Кичтән бажҗайга барып, көтүне иртәнге эңгер-меңгердә үк алып чыгарга куштым.* В.Нуруллин

**2.** *с. мәгъ.* Ярымкараңгы. *Шул вакытта аяк очымда сәкедә бөкрәеп утырган бер кешегә күзем төште. Эңгер-меңгер вакыт булганга, аның кем икәнен аерып күреп булмый иде.* Гали Рәхим. --- *ерак түгел, бик зур булмаган, эңгер-меңгер вакытның серлелеген үз эченә алган көмеш күл җәйрәп ята иде.* А.Нәҗми

**ЭОГИ́ППУС** *и. гр. зоол.* Атның моннан 50 миллион еллар чамасы элек яшәгән иң борынгы бабасы. *Эогиппус урманнарда, елга буйларында яшәгән.* Дарвинизм нигезләре

**ЭОЛИТ** *и. археол. иск.* 1) Таш чорының – палеолитның иң борынгы периоды. *Эолит чоры*

2) Борынгы таш коралга охшаган үткен кырлы таш кыйпылчыгы (күпчелек галимнәр, эолитлар кеше катнашыннан башка, ягъни табигый көчләр тәэсире нәтиҗәсендә барлыкка килгән, дип исәплиләр)

**ЭПАТАЖ** *и. фр. кит.* **1.** Гаугалы, сәер, үз-үзеңне тотуның гомуми кабул ителгән кагыйдәләрен боза торган гамәл, кыланыш, тәртип. *Пётр, киенепясанып тамаша күрсәтүчеләр шикелле, эпатаж яраткан һәм җәмгыятьнең гадәти нигезләрен үзгәртү белән мавыккан.* Р.Хәким

**2.** *с. мәгъ. ялг. к.* **эпатажлы**

**ЭПАТАЖЛА́У** *ф. кит.* Гаугалы кыланышы, гомуми кабул ителгән кагыйдәләрне бозуы белән халыкны гаҗәпкә калдыру; эпатаж тудыру

**ЭПАТАЖЛЫ** *с.* Эпатажга корылган, эпатаждан гыйбарәт. *Юк-юк, мин үзебезнекеләрне теге ике атакай кебек тыйнаксыз, эпатажлы интервьюлар биреп йөрергә өндәмим.* Мәдәни җомга. *Ул чор өчен бу – шактый үзенчәлекле һәм эпатажлы картиналарның берсе була.* Яңа тормыш

**ЭПАТАЖЛЫК** *и. ялг. к.* **эпатажлылык**

**ЭПАТАЖЛЫЛЫК** *и.* Үз-үзен тотуына, гамәл, кыланыш, тәртибенә эпатаж хас булу, эпатаж белән мавыгу гадәте. *Иң аяныччысы, дип яза А.Кончаловский, яшь буын кешеләренең әлеге «эпатажлылык, эстетик хулиганлык» җимешләрен югары сәнгать үрнәкләре дәрәҗәсендә кабул итүләре.* Л.Мингалиева

**ЭПЕНТЕ́ЗА** *и. гр.* Фонетик үзгәреш тәэсирендә сүз эченә аваз, хәреф яки иҗек өстәлү (мәс., *барасызмыни – барасыгызмыни*). *Эпентеза булганда – аваз сүз уртасына өстәлә.* Ф.Сафиуллина. *Эпентеза яки алынма сүз уртасына аваз өстәлү татар теленә хас булмаган ике янәшә килгән тартыкны таркату өчен кулланыла.* Г.Мөгътәсимова

**ЭПИГОН** *и. гр. кит.* Нинди дә булса фәнни, сәяси яки әдәби юнәлешкә сукырларча иярүче, иҗади үзенчәлектән мәхрүм булган, үзеннән алдагы кешеләрнең искергән идеяләрен, методларын механик кабатлаучы кеше; тәкълитче. *Бу тавышта без күбрәк Такташ нюансларын ишетәбез. Илдар Такташны кабатламый! Ул Такташ иҗатының эпигоны түгел.* Х.Туфан. *Аерым алганда, Г.Толымбайский аны «солтангалиевче» Бурнашның эпигоны дип атый.* Ф.Галимуллин

**ЭПИГОНЛЫК** *и. кит.* Фән, әдәбият, сәясәт һ.б.ш.да нинди дә булса юнәлешкә яки берәр эшлеклегә сукырларча иярү, иҗади, мөстәкыйль эш итәргә сәләтсезлек. *Такташтагы шул гүзәл үзенчәлекнең кайбер эпигоннары булды ---, ләкин безнең әдәбиятны эпигонлыктан, я Рабби, үзең саклый күр.* Х.Туфан. *Бабичның Тукай, Дәрдемәнд, С.Рәмиев традицияләрен дәвам итүе аның иҗатын һич тә эпигонлыкка төшерми.* Д.Заһидуллина

**ЭПИГРА́ММА** *и. гр. әд.* 1) Борынгы грекларда һәйкәлләргә, биналарга, кабер ташларына, бүләкләргә һ.б.га шул предметның әһәмияте һәм мөһимлеге турында язылган прозаик яки шигъри язма

2) Кемгә яки нәрсәгә карата төртмәле, чәнечкеле итеп язылган кыска сатирик шигырь; шундый шигырь жанры. *Ода-мәдхияләр, эпифания-мәрсияләр, элегияләр, --- эпиграммалар, җырлар – әчтәлек буенча да, төзелешләре буенча да билгеле бер тотрыклылыкларын саклаган лирик жанрлар һаман да туа торалар.* Н.Юзиев. *XX гасыр татар поэзиясендә эпиграмма жанрына күп шагыйрьләр ишек шакыды.* Т.Галиуллин

**ЭПИ́ГРАФ** *и. гр.* 1) Борынгы грекларда кабер ташларындагы язу

2) *әд.* Автор тарафыннан әсәрнең яки аның берәр бүлегенең башында бирелгән һәм шушы әсәрнең, бүлекнең төп идеясен яктырткан гыйбарә, гадәттә кайдан да булса алынган аерым цитата, мәкаль, әйтем. *Шушыңа охшашлы җыр «Казан утлары»ның җитмеш алтынчы елгы өченче санында Стәрлетамакта нәшер ителгән китаплар турындагы мәкаләгә эпиграф буларак басылып чыкты.* М.Әмир. *Шагыйрь, иң әүвәле, эпиграф урынына Тукайның «Ни сәбәптән җир йөзендә тәнгә – мунча, җанга – юк?» дигән шигырь юлын язып куйган.* Н.Юзиев

**ЭПИГРА́ФИК** *с.* Эпиграфикага мөнәсәбәтле, эпиграфикага караган. *Һ.Йосыпов бу авыл зиратында XIV йөзгә мөнәсәбәтле кабер ташы язмалары таба. Шулай ук ул күршедәге Өбрә, Айбаш һәм Мәмдәл авылларында да шушы чорга караган эпиграфик истәлекләрне билгели.* Ф.Гарипова. *Әтрәч зираты – Урта Идел регионының борынгы чордан сакланып калган иң зур эпиграфик комплексы!* А.Сункишев

**ЭПИГРА́ФИКА** *и. гр.* 1) Кабер ташларындагы язмаларны өйрәнә торган фән тармагы, ташъязмалар фәне

2) Билгеле төбәк, чор һ.б.ш.га караган ташъязмаларның барысы. *Мәсьәләнең өйрәнелү тарихына килгәндә, төбәк эпиграфикасы хакында әлегәчә фәнни мәкаләләр язылганы юк диярлек.* М.Әхмәтҗанов. *Шәһре Болгарның һәм Болгар йортының эпиграфикасы яхшы ук өйрәнелгән ---.* С.Алишев

**ЭПИГРАФИСТ** *и. гр.* Эпиграфика белгече. *Эпиграфист Һ.Йосыпов Әлдермеш авылы зиратында XVI йөзнең беренче яртысында куелган кабер ташлары таба.* Ф.Гарипова. *Эпиграфистлар 2001–2002 һәм 2004 елларда яз-көз айларында районның барлык авылларында каберлекләрне тикшерә.* Мәдәни җомга

**ЭПИДЕ́МИК** *с.* 1) Эпидемия характерындагы, эпидемия үзенчәлеге булган. *Шул вакытта әллә каян килгән эпидемик авыру калган халыкны кырып бетерә.* Г.Исхакый. *Грипп һәм башка эпидемик авырулар язга таба калкып чыга.* Идел

2) Эпидемиягә каршы көрәш белән бәйле булган. *Чит ил гражданнары ил-*

*дәге эпидемик вазгыятькә тискәре йогынты ясарга: ВИЧ-инфекция, вируслы гепатит, малярия, туберкулёз, хәтта Эбола һәм Зика авыруларын таратучылар булып торырга мөмкин.* Казан утлары. *Илебезнең 20 субъектында инде чирләүчеләр исәбе эпидемик чиктән узып киткән.* Мәйдан. *Эпидемик чаралар*

3) *күч.* Эпидемия шикелле барлык җиргә таралган, һәр җирдә булган

**ЭПИДЕМИО́ЛОГ** *и. гр. мед.* Эпидемиология белгече. *Дизентерия башланса, эш харап. Эпидемиологлар бу мәсьәләдә бик шәфкатьсез: --- әллә ниткән трубаларын күтәреп килеп, өеңә дезинфекция ясарлар.* М.Мәһдиев. *Корчаңгы авыруы 30 елга бер тапкыр «кабынып» ала, дип фаразлый эпидемиологлар.* Юлдаш

**ЭПИДЕМИОЛО́ГИК** *с. мед.* Эпидемиологиягә мөнәсәбәтле, эпидемиологиягә караган. *Талпан энцефалиты, котыру чире кебек эпидемиологик ситуацияләр аеруча борчу тудыра, дип исәпли белгечләр.* Татарстан яшьләре

**ЭПИДЕМИОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Эпидемияләрнең килеп чыгу, таралу сәбәпләрен өйрәнә һәм аларга каршы көрәш чараларын эзли торган медицина тармагы; йогышлы авырулар турындагы фән. *Авыруның табигатен тирәнрәк ачыклау теләге аны этиология, патогенез, эпидемиология һәм башка тармакларга да алып керә.* Т.Әйди. *Күренекле галим беренче көнне «Үпкәдә яман шеш» дигән темага лекция укыды, эпидемиология, фаразлар, скрининг, инвазияле хирургия үзенчәлекләре турында бәян итте.* Фән һәм тел

**ЭПИДЕ́МИЯ** *и. гр. мед.* 1) Билгеле бер территориядә нинди дә булса йогышлы авыруның киң таралуы, кизү, мур. *Җитмәсә, грипп эпидемиясе булу сәбәпле, больница авырулар белән тулган, Гөлшәһидә аларны урнаштырырга урын таба алмыйча тәмам алҗып бетте.* Г.Әпсәләмов. *Шәһәр халкын ваба, тиф эпидемияләре дә онытып бетерми.* Р.Мостафин

2) *күч.* Бик тиз таралып китә торган күренеш. *Марҗа кулы белән затлырак кәнәфигә утырырга теләүче һәм теләгәнә ирешкән галимнәр барлыкка килде. Бу эпидемия бүген дә дәвам итә.* Т.Миңнуллин. *Яңа гына барлыкка килгән гаиләләрнең яртысына якыны бер-ике елда таркала икән, бу инде бер төрле кысаларга да сыймый. Бу – үзенә күрә афәт, эпидемия сыман күренеш.* М.Әхмәтҗанов

**ЭПИДСТА́НЦИЯ** *и. рус* Эпидемиология станциясе; эпидемияләр булдырмау өчен профилактик эш алып бара торган учреждение. *Эпидстанция кебек хәзерге заманның җаваплы участогында шундый таләпчән --- кеше утырганда, сезгә --- файда гына түгелмени, Нур Фатыйхович?* А.Гыйләҗев. *Хатын бәлешкә якын да бармый, эпидстанция кешеләре ашап туя алмый, минсинайтим.* Р.Төхфәтуллин

**ЭПИЗОД** *и. гр.* 1) Тормышта булган нинди дә булса бер очрак, вакыйга. *Хәтердә сеңеп калган икенче эпизод: Зиннәт иптәш малайлары белән берәүләрнең яшелчә бакчасын басмакчы булды.* Р.Кәрами

2) *кит.* Нинди дә булса эзлекле процесс, вакыйга, күренеш, хәл һ.б.ш.ның вакыт, урын яки башкача чикләнгән бер өлеше, кисәге. *Фәрит Хәбибуллович --- элеграк үзенең эш практикасында очраган куркыныч җинаятьләрне тикшерү эпизодларын исенә төшерде ---.* Ф.Вәлиәхмәтов. *Күз алдында өзек-өзек картиналар, әле генә сөйләнгән вакыйганың аерым эпизодлары, кешеләр, аларның йөзләре...* Р.Кәрами

3) Кыска вакытлы, очраклы хәл яки вакыйга. *Имән төбендә утырган кич – ул бер очраклы эпизод кына ---.* А.Гыйләҗев

4) Әдәби әсәрнең чагыштырмача, теге яки бу дәрәҗәдә тәмамланган яки мөстәкыйль кисәге. *Язучы әсәрдә мондый сынауның гаять оригиналь бер формасын сурәтли: Сарсымбай авылының икенче бер җәйләүгә күчүе вакытында ат өстендә уйнаклап барган Карлыгач-Сылуның Арысланбай белән очрашу эпизоды.* М.Хәсәнов

5) Кинокартинаның сюжет ягыннан төгәлләнгән бер кисәге, өзеге. *Фильм башында Наилә, Рәхимгә елыша барып, теге яки бу эпизодка үзенең мөнәсәбәтен белдерә торды.* А.Вергазов. *[Фильм өчен] күпчелек эпизодлар Ямал-Ненец автономияле округында төшерелде.* Юлдаш

6) Театрда вакыйгаларның үсеше белән бәйләнмәгән өстәмә күренеш

**ЭПИЗО́ДИК** *с.* 1) Системалы рәвештә булмаган, бер очрактан икенче очракка кадәр генә була ала торган, әллә нидә бер, көтелмәгән. *--- биредә бер-ике атна чамасы Я.А. Пономарёв белән М.Г. Худяков, 1928 елда ун көн буена А.С. Башкиров экспедицияләре эшли. Әмма эпизодик характердагы бу казылмаларның нәтиҗәсе әллә ни зур булмый.* М.Хуҗин. *Мондый эпизодик бәла-казаларга 1552 елдан башлап эзлекле рәвештә уздырылган миссионерлык сәясәте дә өстәлгән ---.* Мирас

2) Очраклы; төп, нигез итеп исәпләнми торган. *--- татар поэзиясендә кыска шигырьләрнең төрле формалары --- аз һәм эпизодик характерда булу сәбәпле, әлеге авторлар иҗатының төп юнәлешен һәм эчтәлеген билгели алмадылар.* Р.Фәйзуллин

3) Аерым эпизодларда, күренешләрдә генә катнаша торган; төп геройларга һәм төп сюжетка карамаган. *--- ул --- гап-гади артистка. Аның да шөһрәт казанмаганы, сәхнәгә керепчыгып йөри торганы гына. Үзләре телендә андыйларны эпизодик рольләрдә уйнаучы дип атыйлар бугай.* И.Юзеев. *Р.Төхфәтуллин әсәрләрендә фон өчен генә алынган эпизодик персонажлар еш кабатлана.* Татар әдәбияты

**ЭПИЗОДЛЫ** *с.* Билгеле эпизодлардан торган. *Вакыйгага корылган (ягъни сюжетлы) мәзәкләр, кагыйдә буларак, бер эпизодлы була.* Л.Җамалетдинов

**ЭПИЗОДЛЫЛЫК** *и.* Билгеле эпизодлардан тору; эпизодлы булу. *Ә драманың җитешсезлеге итеп саналган күп эпизодлылык, вакыйганың төрле урыннарда баруы --- сценарийның табигый хасияте һәм отышлы яклары булып киткән.* Н.Юзиев

**ЭПИЗОО́ТИЯ** *и. гр.* Хайваннар арасында нинди дә булса йогышлы авыруының шактый зур территориядә киң таралуы; кыргын. *[Ногман:] Бозауларда була торган ак тизәк, паратиф, сыерлардагы инфекцион аборт яшь терлекләрне үрчетүгә каршы иң куркынычлы эпизоотияләрдән санала.* Т.Гыйззәт. *Декабрь аенда Бөгелмә, Богырыслан, Бузулук һәм Николаев өязләрендәге татарлар һәм башкортлар эпизоотия очракларында мал-туарны үтерүгә каршы чыгалар.* Гасырлар авазы

**ЭПИЗООТОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Ветеринариянең хайваннар арасында йогышлы авыруларның килеп чыгу, таралу сәбәпләрен һәм закончалыкларын өйрәнү, аларга каршы көрәш чараларын эзләү тармагы. *10 мартта --- ветеринария вирусологиясе һәм эпизоотологиясе өлкәсендә күренекле белгеч, эпизоотология лабораториясе мөдире, ветеринария фәннәре докторы, профессор Харис Зариф улы Гаффаровның җитмеш яше тулган көне билгеләп үтелде.* Фән һәм тел

**Э́ПИК** I *и.* Эпослар авторы, эпос жанрында иҗат итүче

**Э́ПИК** II *с.* 1) Эпос жанрына караган, эпос саналган. *Лирик поэзия дә, эпик поэзия дә заманның рухын, бүгенге кешенең хисләрен яңача бирү өчен эзләнә.* И.Юзеев. – *Эпик жанр минем өчен ят, әти. Мин хәзерге көнне язам, хәзерге көн геройларын, – дип акланды Мәҗнүн.* Х.Ибраһим. *Халыкның борынгы бабалары, алыплар һәм батырлар турында риваятьләр --- – болар барысы да төркиләрнең поэтик эпик иҗатында чагылыш таба килгәннәр.* Р.Әхмәтьянов

2) Эпоска охшаган, эпос кебек

3) Эпоска хас. *Эпик ысул белән саллы итеп хикәяләве, образларның масштаблы --- булуы ягыннан «Михнәтле заман» трилогиясе роман-эпопея санала.* Х.Сарьян. *Тукай булган урыннар илһамлануга һәм күпсанлы лирик, эпик пейзажлар тудыруга мөмкинлек бирделәр.* Д.Хисамова

4) *күч.* Күтәренке, тантаналы, тыныч. *Эпик тон*

**Э́ПИКА** *и. рус әд.* Эпик әсәрләр. *Эпос, эпика, --- кебек әйтелешләр телебезнең табигатенә авыр булып, әлегә хәтле киң кулланылмыйча, белгечләр телендә генә йөри.* Н.Исәнбәт. *Барлык жанрларда – формалар, сюжетларда – психологик драмамы ул, эпика, --- фарс яки мелодрамамы – барысында да --- режиссёр тарафыннан уйланылган төзеклек белән оешканлык чагыла.* Татар театры

**ЭПИКАРД** *и. гр. анат.* Йөрәкнең тышкы сүрүе, пәрдәсе

**ЭПИКАРДИТ** *и. гр. мед.* Эпикардның, йөрәк тышчасының ялкынсынуы

**Э́ПИКЛЫК** *и.* Эпик форма, алым; эпоска хас сыйфатлар. *Мишәрнең озын көйләрендә --- эпиклык, борынгылык аермачык сизелеп тора.* Э.Касыймов. *Хикәят – Шәрык әдәбиятларында (аеруча Урта гасырларда) гаять киң таралган жанр төре. Аның өчен эпиклык, хикәяләү хас.* М.Хуҗин

**ЭПИКРИЗ** *и. гр. мед.* Авыруның тарихы язылган кенәгәдә диагнозны нигезләгән, дәвалауның барышы һәм нәтиҗәләре, дәвалау буенча рекомендацияләр теркәлгән язма, белешмә. *Раилә апада андый кәгазь юк, амбулатор картада да хастаханәдә ятып чыгуы турында эпикриз күчерелмәсе ябыштырылмаган.* Ватаным Татарстан

**ЭПИКУРЕИЗМ** *и. рус* 1) Борынгы грек фәлсәфәчесе Эпикур тәгълиматы. *Эпикуреизм Аристиппның ләззәтләр этикасы белән Демокритның атомнар турындагы тәгълиматына нигезләнгән. Эпикуреизм фәлсәфәсе*

2) Яшәүнең бар мәгънәсен рәхәт һәм ләззәттә генә күрү, шундый карашларга нигезләнгән яшәү рәвеше

**ЭПИКУРЕЙЧЫ** *и. ялг. к.* **эпикурчы**

**ЭПИКУРЧЫ** *и.* 1) Эпикуреизм тарафдары

2) Яшәүнең бар мәгънәсен рәхәт һәм ләззәттә генә күрүче кеше

**ЭПИЛЕ́ПСИЯ** *и. гр. мед.* Баш миенең әледән-әле көзән җыеру, аң югалту белән характерлана торган хроник авыруы; өянәк, зыяндаш авыруы. *Бу хәлләрдән Миргалим исемле картның өянәк чире кузгалды, ул эпилепсия чиреннән идәнгә барып төшеп, тартыша, гырылдый башлады.* Ф.Бәйрәмова. --- *ул эпилепсия белән авырый, һәм кайчагында авыруы безнең каршыда тота – кинәт яман ачы тавыш белән кычкыра да җиргә егыла, бәргәләнә.* А.Тимергалин

**ЭПИЛЕ́ПТИК** I *и. гр. мед.* Эпилепсия белән авыручы кеше. *Хуҗасы әйтүенчә, Титанның күзләре дә күрми, колаклары да ишетми, өстәвенә, ул эпилептик та.* Татарстан яшьләре

**ЭПИЛЕ́ПТИК** II *с. гр.* Эпилепсия белән бәйле булган. *Шуннан соң электр энцефалографиясе үткәрәләр, ул эпилептик активлыкның юкка чыгуын күрсәтә.* Сөембикә

**ЭПИЛОГ** *и. гр.* 1) Борынгы грек драмасында тамашачыларга автор ниятен аңлатып бирә торган соңгы мөрәҗәгать

2) *әд.* Әдәби әсәрнең, әсәрдә сурәтләнгән вакыйгалардан соң, геройларның язмышы турында сөйләнә торган тәмамлану өлеше. *Алар шул пәрдә фонында моннан унике ел элек башлап җибәргән спектакльнең эпилогын уйнадылар.* М.Маликова. *Әсәрнең эпилогында татар һәм рус туйлары матур гореф-гадәт буларак тасвирлана.* Ә.Закирҗанов

3) *муз.* Кинофильм, музыка әсәре һ.б.ш.да тәмамлану күренеше

4) *күч.* Нәрсәнең дә булса соңгы чоры, соңгы өлеше, йомгагы, ахыры, чишелеше

**ЭПИЛЯ́ТОР** *и. гр.* Эпиляция ясау өчен махсус әсбап яки прибор. *Үлчәү, ябыгу чаралары, эпилятор.* Шәһри Казан. *Әмма сакал-мыек чамадан тыш күп һәм куе булса, бернинди эпилятор да коткара алмый икән.* Татарстан яшьләре

**ЭПИЛЯ́ЦИЯ** *и. гр. мед.* Матурлык өчен яки берәр башка максат белән тәндәге төкләрдән арыну процедурасы. *Ул үзенчә аңлата – үзен хөрмәт иткән һәр хатын-кыз әзерлек этабын узарга тиеш, ди: пилинг, эпиляция ясату, йөзү костюмы сатып алу һәм, гомумән, җәйге гардеробны яңарту, чәч кистерү, маникюр, педикюр...* Сөембикә

**ЭПИПРОЕ́КТОР** *и. гр.-лат. махс. к.* **эпископ**

**ЭПИСКОП** *и. гр.* Үтәли күренми торган рәсемнәрне, предметларны экранда күрсәтү приборы

**ЭПИСТЕМОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Фәлсәфәнең танып белүне, белемне, аның төзелешен, үсешен өйрәнә торган тармагы

**ЭПИ́СТОЛА** *и. гр. әд. иск.* XVIII–XIX гасыр әдәбияты жанры; хат формасында язылган әсәр

**ЭПИСТОЛЯР** *с. әд.* 1) Эпистолага хас

2) Хатлар формасында язылган. *Эпистоляр жанрда – хатлар рәвешендә язылган бу поэма минем үземә ошады.* Р.Миңнуллин. *Әдәбият киң мәгънәдә, язма шәкелдә иҗат ителгән һәртөрле әсәр, дигәнне аңлата. Аңа фәнни, публицистик, белешмә, эпистоляр һәм башка төрле әсәрләр керә.* К.Гыйззәтов

3) Хатлардан торган, хатлар җыелмасын тәшкил иткән, хатлар төрендәге. *Әдәбият институтында укыганда, ул безнең Диләрә Зөбәерова белән берничә еллар хат алышкан икән! Араларында, шиксез, гаҗәеп матур эпистоляр роман булган, хатлар да, шигырьләр дә йөргән ---!* Р.Гаташ

**ЭПИТАЛА́МА** *и. гр.* 1) Антик поэзиядә һәм музыкада яңа өйләнешүчеләрне котлау җыры

2) Өйләнешү, кавышу хөрмәтенә язылган шигырь

**ЭПИТА́ФИК** *с.* Эпитафияләргә караган. *Төбәк тарихында эпиграфик истәлекләрне барлауның беренче тәҗрибәсе булган бу китап Әлмәт якларында мәгълүм 110 зираттагы эпитафик язмаларны фәнни экспедиция оештырып өйрәнү нигезендә язылды.* М.Әхмәтҗанов. *Элеккеге язма истәлекләрдә, аеруча эпитафик ядкәрләрдә «дарелбәка» (мәңгелек йорт, ягъни теге дөнья) «дарелфәна» (вакытлы йорт, ягъни бу дөнья) --- гыйбарәләре күзгә еш ташлана.* Мирас

**ЭПИТА́ФИЯ** *и. гр.* Кабер ташындагы язма, кабер ташъязмасы. *Бу эпитафияләрнең нәкъ менә болгарларда таралуын тикшерүче галимнәр ислам*

*дине, мәдәнияте һәм мәгарифе үтеп керүе белән аңлаталар.* С.Алишев. *Мин синең кабер ташыңа яза торган эпитафия уйлап чыгардым ---.* З.Зәйнуллин

**ЭПИ́ТЕТ** *и. гр. әд.* 1) Сөйләмнең яки әсәрнең сәнгатьлелеген, поэтик көчен арттыру өчен, нәрсәнең яки кемнең дә булса уңай, матур үзенчәлеген күрсәткән, соклануны, мактауны белдергән сүз. *Хәзер әни турында язу модалы бер эшкә әйләнде, әниләр турында бик күп җырлар язылды. Кызганычка каршы, әни турында язганда, мин бу эпитетларны, метафораларны кабатлый алмыйм.* М.Мәһдиев. *Ә бит ул «матур иртә» дип әйтер алдыннан, шушы мәлне унлап эпитет белән тасвирлап, конкрет сурәтләп бирә ---.* И.Низамов

2) *лингв.* Бер исем янында даими кулланыла торган сыйфат (мәс., *тулган ай, мул уңыш, ачык йөз*)

3) *ирон.* Сүгү сүзе. *Кызып китеп, әллә нинди эпитетлар тезде*

**ЭПИФА́УНА** *и. гр.-лат.* Сулыклар төбендәге грунтка, кыяларга, ташларга берегеп яши торган яки аз хәрәкәтләнүчән умырткасыз хайваннар комплексы (моллюсклар, энәтиреләләр, полихеталар, кайбер кысласыманнар һ.б.)

**ЭПИФИЗ** *и. гр. анат.* 1) Баш мие өстендәге өстәмә үсенте формасындагы, эчке секреция системасына караган шешсыман биз. *Тычканнарның эпифиз бизен алып ташлау тәүлеклек ритмнар югалуга китерми.* Сәламәтлек нигезләре. *Начар йоклаучы кешенең эпифиз бизе тагын бер әһәмиятле гормон – мелатонин дип аталучы йокы гормонын бик аз бүлеп чыгара.* Фән һәм тел

2) Көпшә сөякләрнең киңәеп, йомрыланып торган очы

**ЭПИФИТ** *и. гр. бот.* Башка үсемлектә үсеп тә, паразит булып яшәми торган үсемлек. *Тропик урманнарда эпифитлар бик күп, алар анда агачларның кәүсә һәм юан ботак кайрыларында үсә.* Ботаника. *Сәхләбчәләр семьялыгы арасында төрле тереклек формасы үсемлекләре – эпифитлар, лианалар, коры җир өсте төрләре очрый.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**ЭПИ́ФОРА** *и. гр. әд.* Шигырь юллары, фразалар һ.б.ш. ахырында бер үк сүзләрне яки сүз тезмәләрен кабатлаудан гыйбарәт стиль алымы. *Г.Кандалыйның шигырь-поэмаларында махсус һәм синтаксик сурәтләү чараларыннан эпитет, метафора, гипербола, антитеза, чагыштыру, анафора, эпифора --- һ.б. матур үрнәкләре белән очрашабыз.* Ә.Закирҗанов

**ЭПИЦЕНТР** *и. гр.-лат. махс.* 1) Җир тетрәү һ.б.ш. табигый яки башка җимергеч көчләрнең җир өслегендәге үзәге туры килгән урын. *Әгәр эпицентр диңгезгә туры килсә, бик көчле диңгез дулкыны күтәрелә, һәм якында булган яр буйларын су баса.* А.Фәткуллин. *Бомба шартлаткан урынга танкка утырып барып, берничә мәртәбә шартлауның эпицентрын карап кайта. Танкны туктатып, чыгып, эпицентрда җәяүләп карап йөри.* З.Зәйнуллин. *Тирәндә токымнар ярылып кучә башлаган урын җир тетрәү учагы дип атала. Җир өслегендә шул урында эпицентр була.* Табигать белеме

2) *күч. кит.* Нинди дә булса күренеш, күңелсезлек, бәла-каза һ.б.ш. үтә көчле чагылган урын. --- *шагыйрь XX гасыр башындагы милли иҗтимагый-рухи яшәешнең үзенә бер эпицентры рәвешендә алга бастырыла.* Татар әдәбияты тарихы. *Эпидемияләр чыганагы кайсы илдә күбрәк очрый? Иң күп вируслар эпицентры – Кытай.* Сәламәт булыйк!

**ЭПОКСИД** *и. хим.* Гади циклик эфирлар төре. *Эпоксид полимер – молекулаларында эпоксид төркеме булган синтетик сумала.* Төзү материаллары

**ЭПОКСИДЛЫ** *с.* Эпоксидлардан торган, составында эпоксидлар булган. *Еш кына плитәләрнең өслеге суга чыдам, феноллы яки эпоксидлы лак белән каплана.* Төзү материаллары. *Шулай ук фотоҗилем яки эпоксидлы җилем дә кулланырга мөмкин.* Бөҗәкләрне энәгә кадау кагыйдәләре

**ЭПОЛЕТЛАР** *и. фр. күпл. махс.* Кайбер армияләрдә, шул исәптән рус армиясендә, офицер, генерал, адмиралларның парад формасындагы, тышкы очы түгәрәкләп, алтын яки көмеш чуклар, тасмалар һ.б.ш. белән бизәкләп эшләнгән погоннары. *Түшләрдә орден, җилкәләрдә алтын эполетлар – шуларның барысы да җирле халыкны кырган, таптаган өчен бирелгән.* М.Юныс. *Суриянең офицерларына карасаң, үзеңнең XX гасырда яшәгәнеңне онытасың. Ул чуклы бүрекләр, чуклы эполетлар, урам ташына бәрелеп йөри торган бизәкле кылычлар.* М.Мәһдиев

**ЭПОНЖ** *и. фр.* Махсус рәвештә тигезле-тигезсез итеп эрләнгән җептән тукылган, шуңа күрә губкага охшаш кытыршырак йөзле мамык яки ефәк тукыма. *[Мәдинәнең] өстендә шакмаклы эпонждан тегелгән кофта белән кара юбка.* Ш.Хөсәенов

**ЭПОПЕ́Я** *и. гр.* 1) *әд.* Борынгы поэзиядә сурәтләнгән вакыйгалары белән бер-берсенә якын торган һәм бер-бер артлы барысы бергә бербөтен булып берләшкән легендаларның, хикәяләрнең, җырларның зур циклы. *Ш.Сарымсаков «Шомлы көннәр»не халык эпопеясы итеп сәхнәгә күтәрә ---.* Д.Гыймранова

2) Тарихи планда зур яки озак вакыт дәвам иткән вакыйгаларны чагылдыра торган эпик характердагы зур күләмле әдәби әсәр. *Язгач-язгач, зур эпопея булсын. Толстойның «Сугыш һәм солых»ы кебегрәк.* Ф.Яруллин. *Рус патшаларының һәрберсе хакында да диярлек фәнни хезмәтләр, романнар, ә кайберләренә багышлап хәтта күптомлы эпопеялар да язылды.* Р.Мостафин

3) Зур, мөһим вакыйгалар, нәрсәнең дә булса катлаулы һәм әһәмияткә ия булган тарихы. *Төрмә эпопеясы үземне дә ялкытты инде. Язарлык, сөйләрлек нәрсә дә калмады шикелле.* М.Әмирханов. *Ир уртасы кеше --- егәрле тормышының бер өлеше узган урынга соңгы, үкенечле карашын ташлый да, гаиләсен алып, башка җиргә күчеп китә. Шуның белән аның Кычытканлы эпопеясы тәмамлана.* Т.Галиуллин

**ЭПОС** *и. гр.* 1) Әдәбиятта, лирика белән драмадан аермалы буларак, хикәяләүнең өч төреннән берсе. *Әдәби төрләрнең башлангыч нигезләрен үз вакытында Гегель бик дөрес күрсәткән: эпос нигезендә – сәнгатьчә үзләштерелгән вакыйга, драма нигезендә – хәрәкәт, лирика нигезендә тойгы һәм рухи халәт ята.* Н.Юзиев. *Дастаннар, эпослар, поэмалар еллардан елларга --- я шул чорлардагы берәр проблемага мәңгелек һәйкәл булып калалар.* Р.Харисов

2) Үткәннәр турында героик халык җырлары, борынгы хикәяләр, поэмалар җыелмасы, халык иҗатының бер жанры. *Без --- һаман әле «Идегәй» эпосыннан, Гаяз Исхакый исеменнән дер калтырап куркып, университетның татар бүлегендә «дебиллар» әзерлибез.* М.Мәһдиев. --- *әлеге карар белән «Идегәй» әсәре ханнар эпосы дип бәяләнде, искә алу тыелган әсәрләр исәбенә кертелде.* Ф.Галимуллин

**ЭПО́ХА** *и. гр.* 1) Җәмгыять, фән, табигать һ.б. үсешендә нинди дә булса әһәмиятле вакыйгалар, күренешләр белән характерлана торган, үзенчәлекләре булган зур вакыт аралыгы, чор, дәвер,

заман. *М.Гафуриның иҗаты татар совет әдәбияты фондына кыйммәтле бер җәүһәр булып кереп калды, һәм ул яшь совет укучыларын --- совет эпохасының беренче чорларындагы көрәш һәм төзү эшләре белән таныштыруда бай материал булып тора.* М.Җәлил. *Җитлеккән социализм эпохасында театр сәнгате тирән эчтәлеккә ия булды. Ул актив милли генә түгел, күпмилләтле колоритлы, үзенчәлекле.* Казан утлары

2) *геол.* Геологик дәвернең – периодның бер өлеше. *Моны шуннан белергә дә була: археологлар әйтүенчә (мәсәлән, Коннова Г.И. буенча) әле бронза эпохасында да, соңрак та Идел – Уралда яшәүчеләрнең дуңгыз ите ашамаганлыклары ачыкланган.* И.Хуҗин. *Экспозиция 40 мең еллык дәверне, ягъни палеолит (таш гасыр) эпохасыннан алып тимер гасыр башланган вакытларга кадәрге чорны үз эченә ала.* Г.Нәҗипова

3) Берәр вакыйга, предмет, күренеш аеруча популяр булган, киң таралыш алган вакыт. *Җирдәге цивилизациянең йөрәк, бавыр, бөер кебек органнарны имплантацияләү дәрәҗәсенә ирешкән чорда, космик сәяхәтләр эпохасында Кеше дигән олуг затларның кайберләре әллә бөтенләй «шизанутый»ларга әйләнеп баралармы, дип уйлыйм мин еш кына.* А.Хәсәнов. *Мини-мода эпохасы.* *Телсез кино эпохасы*

4) *күч.* Берәр өлкәгә аеруча зур һәм әһәмиятле өлеш керткән эшчәнлек чоры. *Аның иҗаты – үзе бер эпоха ул.* М.Сәлимҗанов

**ЭПОХАЛЬ** *с.* Бөтен бер дәвер, эпоха тәшкил итә торган; заманы өчен үтә зур һәм мөһим булган. *XX йөз --- атом энергиясен тудыру, --- кешелекнең башка эпохаль казанышлары белән беррәттән, тормышыбызга килеп кергән «БИТЛЗ» рок-музыка төркеме кебек феноменаль күренешнең тууы белән дә танылды.* Т.Кәримов. *Яңа гасыр башы татар әдәбияты XX йөз башы татар әдәбияты тарихында эпохаль әһәмиятле урын тота.* XX йөз башы татар прозасы

**Э́РА** *и. лат.* 1) Билгеле бер системада еллар исәбе; еллар исәбе башланып киткән вакыт яки вакыйга. *Безнең эрага кадәр V гасырда бер грек сугышчысы Марафон дигән җирдән Афинага кадәр кырык ике километр йөгереп үтә ---.* Кызыклы психология. *Мөгезле эре терлекне кулга ияләштерү безнең эрага кадәр 10 мең еллар элек башланган.* Дарвинизм нигезләре

2) *геол.* Җирнең геологик тарихындагы бүленештә иң зур вакыт берәмлеге (геологик чорларга бүленә). *Африка саваннасы. Саваннада кайнозой эрасында яшәгән казылма җәнлекләргә охшаш ялгыз агачлар.* М.Юныс. *Палеозой эрасы, ятып калган утырма токымнар төренә карап, 5 чорга бүленә ---.* А.Фәткуллин. *Мезозой чорында әнә язучылар үтә дә тыйнак булганнар. Тау куышында рәхәтләнеп яшәгәннәр.* М.Галиев

3) *юг.* Алдагы чорлардан нык аерылып торган тарихи чор; эпоха (*1 мәгъ.*). *Үзе дә бүләксез калмады: аңа «1995–2010 – Татарстан Республикасында автомобиль спортының яңа эрасы» дигән истәлек тактасы бирделәр.* Татарстан яшьләре. *Кешелек тарихының яңа эрасы*

**ЭРБЕТ** *и.* 1) *бот.* Наратчалар семьялыгыннан озын кәүсәле, пирамидаль ябалдашлы, кыйммәтле үзагачлы, мәңгеяшел ылыслы агач; кедр. *Иң беренче салынган йорт аеруча шәп чыкты. Аскы өлеше таштан, өске ягы шәмдәй эрбет, нарат агачларыннан иде.* М.Хәсәнов. *Шулай да эрбет урманына кереп, андагы саф һаваны сулап чыкмыйча булдыра алмадык.* Г.Шәйхи

2) Шул агачның кайбер төрләренең ашарга яраклы майлы чикләвеге. *Чү! Нишләп ул, эрбет чикләвеге җыям дип, шушы куе урманга кереп адашты соң?* Н.Хәсәнов. *Эрбет чикләвеге – Себер эрбет наратының (аны халык эрбет агачы дип йөртә) орлыгы.* Ботаника

3) **Эрбет** Көнчыгыш Уралдагы бер шәһәр; атаклы ярминкәсе белән танылган зур сәүдә үзәге; Ирбит. --- *Урал төбәгендә алыш-биреш белән шөгыльләнүчеләр ешрак Эрбет ярминкәсендә очрашканнар.* Л.Хәмидуллин

**ЭРБЕ́Т АГАЧЫ** *и. к.* **эрбет** (*1 мәгъ.*). *Биек кыя башында мәгърур басып торган пар эрбет агачы иде бу.* Г.Бәширов. *Ылыслылар арасында иң кыйммәтлесе һәм атаклысы – эрбет агачы.* Кызыклар дөньясында

**ЭРБЕТЧЕ** *и. зоол. к.* **эрбет чыпчыгы**

**ЭРБЕ́Т ЧЫПЧЫГЫ** *и. зоол.* Карга кошлар семьялыгыннан куе көрән төстәге, зур-зур таплы кош; эрбетче; *русчасы:* **кедровка, ореховка**. *Алар [Бари белән Сафи], кызыл түшле карабүреклар, эрбет чыпчыклары чыркылдавын --- тыңлый-тыңлый, тайга эченнән сузылган юл буйлап Витимга таба баралар.* Ә.Ибраһимова. *Тайгада суер, эрбет чыпчыгы, очкалак тиен, кеш яши.* Табигать белеме

**ЭРГӘ** *и.* 1) Идән астыннан суык кермәсен өчен, өйнең тышкы дивары тирәләп туфрактан өелгән нигез. *Йортның эргәсе янына ятып торган Караборын, бу күтелмәгән шәһәр киемендәге кунакларны куркытырга теләп, урыныннан сикереп торды ---.* Һ.Такташ. --- *өйләрне әйбәтләп ябасың, сылыйсың, ишек-тәрәзәләрне төзәттерәсең, җылы тотсын өчен, яхшылап эргә саласың, --- күзге өлешкә дип чәчелгән ашлыкларны сугып, келәтнең өсәкләрен тутырасың.* Татар хикәяләре

2) Берәр нәрсәнең яны, тирәсе, кырые. *Шул көнне кичтән --- Сөләйман чишмә башына, йомры таш эргәсенә менде ---.* А.Гыйләҗев. *Кабер эргәсенә якынлашкач --- ак яулыклы апалар, сабыр чырайлы абзыйлар бер якка, ялан-башлы хатыннар, ирләр икенче якка бастылар.* М.Маликова

3) *күч.* Төп йорт, ата-баба йорты; нигез, оя; нәсел, ыруг

4) *күч.* Тәртип, җай, уңай, ип. *Ничектер шулай килеп чыкты: нәкъ шул секундта Рушад тамагын кырды. Хушият абзый, сискәнеп, шул якка карады, --- һәм сүзенең эргәсен югалтты, буталды.* М.Мәһдиев. *Болай тереклек итү никадәрле матур, шигъри һәм бөек булуына карамастан, ул инде үзенең мондый тормыш эргәләренә ятмый торган бүрәнә икәнлеген аңлап бара иде.* Ф.Садриев

**ЭРГӘДӘШ** *с.* **1.** 1) Чиктәш, яннары белән янәшә торган. --- *Кара бәк нәселләре Әгерҗе һәм аңа эргәдәш төбәкләрдәге Исәнбай, Байсар, --- Сарман авылларында утырганнар.* М.Әхмәтҗанов

2) *мат.* Бер яны уртак булган, бер яссылыкта янәшә урнашкан. *Эргәдәш почмаклар*

**2.** *рәв. мәгъ.* Янәшә, күршедә, күрше булып. *Казак далалары белән эргәдәш яшәгән башкортларда да --- атлар куалап алып китү гадәти бер эш, зур егетлек саналган.* З.Зәйнуллин

**ЭРГӘЗЕМБАЙ** *и. диал.* Умырзая. *Эргәзембай чәчәге әле эреп өлгермәгән карны тишеп, кояшны эзләп килеп чыккан да калкулыклар, таулар битен матурлап утыра.* З.Зәйнуллин. *Дәү әни аларны төненә өчәр мәртәбә бик яшь эргәзембай чәчәге төнәтмәсе, кырмыска мае һәм шуның ише бик зәһәр, сасы дарулар сөртеп ышкый.* В.Астафьев

**ЭРГО́ГРАФ** *и. гр. мед.* Кеше мускулларының эшкә сәләтлелегенең үзгә-

решләрен график рәвешендә язып бара торган прибор; эргометрның бер төре. *Эргограф дип аталган приборларда бармак яисә кул белән йөк күтәрү эшен язып алырга мөмкин.* Кызыклы психология

**ЭРГО́МЕТР** *и. гр. мед.* Организмның эшкә сәләтлелеген һәм билгеле эш башкарганда организмда барлыкка килгән функциональ үзгәрешләрне тикшергәндә кулланыла, башкарылган механик эш күләмен үлчи торган прибор

**ЭРГОНО́МИК** *с. гр.* Эргономика таләпләренә туры килә торган; куллануч ы, эшләүче өчен уңайлы, җайлы итеп эшләнгән

**ЭРГОНО́МИКА** *и. гр.* 1) Эш процессын, шартларын, эш коралларын оптимизацияләү максаты белән, конкрет шартларда аерым бер кешене яки кешеләр төркемен өйрәнә торган фәнни дисциплина. *Эргономика таләпләренә җавап бирү*

2) Шул фән таләпләренә туры китереп эшләнгән булу, җайлылык, уңайлылык дәрәҗәсе. *Ул үзенең заманча дизайны, яхшыртылган эргономикасы һәм агрегатлары белән аерылып тора.* Шәһри Чаллы

**ЭРГОНО́МИЯ** *и. гр. к.* **эргономика**

**ЭРДЕЛЬТЕРЬЕР** *и. ингл.* Терьерлар төркеменнән төрле төстәге куе каты йонлы эт токымы һәм шул эт үзе. *Этләр телендә Акмуенның белмәгәне юк, сәмәй көчекләргә генә түгел, бульдог, овчарка, эрдельтерьер кебекләргә дә сөякнең тәме турында, --- кирәксә, дәрес тә бирә алыр иде ул.* Н.Әхмәдиев. *Әлеге юлбасарлар шайкасында этмәэмайлар затының нинди генә данлы, атказанган нәсел вәкилләре юк: озынча танаулы, озын сыйраклы сенбернарлар, --- нечкә билле эрдельтерьерлар, --- кыска аяклы болонкалар, кыланчык ак пудельләр, солдафон кыяфәтле доглар.* А.Хәсәнов

**ЭРЕ** *с.* **1.** 1) Зур күләмле кисәкләрдән торган; *киресе:* **вак**. *Ишек ачылуга, эре роза чәчәкләре төшкән халат кигән апак чәчле Юлия Борисовна --- ярыктан карады.* М.Хәбибуллин. *--- өерелеп, тузан-туфрак күтәрелеп, җилнең кузгалуы да, биткә китереп бәргән эре тамчылары да, --- барысы да --- бик якын иде.* Х.Ширмән

2) Зур, гадәттәгедән зуррак күләмле. *Маркин --- коры җир тирәсендәге су төбенең эре масштаблы картасына төзәтмәләр кертте.* А.Мифтахетдинов. *Ләкин мин күзәткән егет – крестьян егет иде: зур куллы, озын гәүдәле, эре аяклы.* М.Мәһдиев

3) Гадәтидән зуррак үлчәмдәге; киң, озын. *Сабир, сөйләнә-сөйләнә, эре адымнар белән алга атлады.* А.Алиш

4) *а.х.* Сыер, үгез, буйвол, як кебек мөгезле йорт хайваннарын берләштергән. *Авыл балалары белә торганнардыр: бигрәк тә салкын көзге көннәрдә тана, бозау, сыер ише эре маллар тау итәкләренә --- китеп, «кайтырга онытлар».* Ж.Дәрзаман. *--- кайбер урыннарда эре терлекне башта электр тогы ярдәмендә аяктан егалар, аннан соң гына чалалар.* Инсан һәм дин // Гомумән сыер, үгез, ат, дөя һ.б. зур йорт хайваннарын берләштергән. *Эре малны инде әйтәсе юк: Әнә Газиз картның колыны, Үз анасын эзләп, җиз быргыдан Яңгырата ерак болынны.* А.Хәлим

5) Киң масштаблы; составы зур булган. *Ләкин бу дәһшәтле указ да көткән нәтиҗәне бирми, бары тик, дәүләтен саклар өчен, күп җир биләүче эре алпавытлар гына ашыгып чукыналар ---.* Ә.Еники

6) Көче, мөмкинлекләре, йогынтысы һәм кыйммәте ягыннан зур; әһәмиятле; дәрәҗәле. *Эре капиталдан мәхрүм калуны бер җамаяк ашсыз калу дип кенә уйларга ярамый.* Л.Шагыйрьҗан

7) Зур кыйммәтле, зур бәяле. *Җыймак өчен безгә бирелгән эре акча бар иде.* Дастан. *Акчалар бик эре: унлык – кара-көмеш сурәтле, утызлык – озын, кызгылт алсу, йөзлек – тастымал буе.* М.Мәһдиев

8) *күч.* Тәкәббер, масаюлы, һавалы. *--- шул арада эре кыяфәт белән тырттырт басып, --- кызыл кикрикле купшы әтәч килеп чыкты.* Н.Фәттах. *--- шофёрың үзеңнән тәбәнәк, койгырыш кына бер мәхлук булсын. --- Әгәр ул мәһабәт гәүдәле, эре кыяфәтле, җитмәсә, акыллы да булса... шофёрны – син, сине шофёр дип бутаулары мөмкин.* М.Галиев

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Киң алып, озын ясап, зур итеп. *Эре-эре атлап, яңадан мунчага таба китеп барды.* Ф.Латыйфи. *Әнием бер атлаганны Мин вак-вак биш атладым. Ул елмаеп карый килде: – И, балакай, синең адым... Инде хәзер киресенчә – Мин эре атлый башладым.* Ш.Галиев. *Итне эре турагансың*

2) *күч.* Масаеп, тәкәбберләнеп. *Җыелышта Талип үзен гадәттәгечә эре тотты һәм алган сүзен шулай тәмамлады – аңа калса, аның белән һәммәсе килеште.* М.Хәбибуллин. *Секретарь ярты сәгатьтәнме, бер сәгатьтәнме эре генә дәү ишеккә ымлагач, ул, каударланып, ишеккә ташлана ---.* Р.Зәйдулла

**3.** *и. мәгъ. диал.* Онны иләгәннән соң иләк өстендә кала торган кибәк, көрпә. *Иләктәге эрене бозауга болгатып бирдем*

◊ **Эре бавырлы** Бик масаючан, тәкәббер, һавалы кеше турында. **Эре бәрәңге** Абруйлы, урындагы һ.б.ш. кеше; үзен зурга куючы кеше. *Язуында да ул полковник каршында үзенең шактый эре бәрәңге икәнлеген күрсәтергә тырышты.* С.Поварисов. **Эре бәрәңге ашаган** Эреләнгән, тәкәбберләнгән, масайган. *– Егетебезнең әнисе бик усалдыр, ахрысы, кызларга карама, дип әйтеп җибәргәндер. – Егетмени ул, поломучный бит. – Безгә килгәч эре бәрәңге ашаган. – Егерме кызга – бер егет, эреләнерлек тә шул.* Ә.Баян. **Эредән җибәрү** *к.* **эредән кубу**. **Эре иләктән иләү** 1) Эшне аннан-моннан гына эшләү; 2) Тикшерү, сайлап алу һ.б.ш. эшләрдә беренчел, гомумирәк таләпләр кую, артык җентекләмәү, иң начарларын гына төшереп калдыру. **Эре иләктән үткәрү** *к.* **эре иләктән иләү**. *Шул белем белән без, сепарат авызына салган сөт кебек, имтиханга агылып кереп киттек, – алты йөз утызы гына торып калды. Инде шулар эченнән, башта эре иләктән генә үткәреп, кырык сигез урынга туксан алты кеше кабул иттеләр ---.* Х.Сарьян. **Эредән кубу** 1) Гадәти булганнан зуррак эшләр белән шөгыльләнү; 2) Әллә ни булдыра алмаса да, булдырган кебек артык эре сөйләшү, һавалану. *Теге вакыттагы үсмер оялчыклыгын эредән кубып сөйләшерлек өстенлек алыштырды.* М.Галиев. *Болай эредән кубып сөйләшүгә ул гына түгел, Назыйм да тотынмас иде, әмма Ленар кузгалгач, моннан читтә калмады.* Р.Айзатуллин. **Эре сөякле** Таза, олы гәүдәле. *Эре сөякле, юан беләкле егетләрнең сугыштан нибары берсе култык таяклары белән әйләнеп кайтты...* М.Мәһдиев. *Ишек катында, түргә үтим микән, юк микән дип, шактый олы яшьләрдәге бер карт басып тора иде. Карт киң җилкәле, эре сөякле.* М.Хәбибуллин. **Эредән сукалау** *к.* **эредән кубу**. *– Алай ук эредән сукаламасаң да ярар, якташ, – дип әйтеп куя Зәки Вәлиди, рәсмилекне өнәмичә.* Р.Мөхәммәдиев. **Эредән яру** *к.* **эредән кубу**. *– Юк, – диде бу иптәш, саран гына елмаеп. – Кармак салып*

*утырырга туры килгәне юк. Берәмләп тоту гына мине кызыксындырмый. «Эредән яра абзый кеше», – дип уйлап алдым мин ---.* Ә.Еники. **Эре чирттерү** Арттыру. – *Яшерми генә әйтегез, кулыгыздан нинди эш килә? – Барысы да! – дидем мин, эре генә чирттереп.* М.Сәлим

**ЭРЕ** *и. сканд.* Швеция, Дания һәм Норвегиядә кронаның йөздән бер өлешенә тигез вак акча

**ЭРЕЛӘНДЕРҮ** *ф.* 1) Зурайту, эрегә, зурга әйләндерү

2) Берничә хуҗалык яки административ берәмлекне берләштерү, шулардан бер зур берәмлек оештыру. *Авылларны эреләндерү, беренчедән, кемнең дә булса теләү яки теләмәвенә карамаячак. Тормыш үзе шуңа этәрә.* М.Мәһдиев. *Эреләндерелгән кайбер колхозларда үзәк утардан читтәге авылларга үгисетебрәк карау беркемгә дә сер түгел.* Р.Гәрәй

**Эреләндерә бару** Булган берсен берәм-берәм акрынлап эреләндерү. *Һәр 5–10 көн саен ике сакманны бергә кушып эреләндерә баралар.* Сөембикә. *Колхозларны һаман эреләндерә бардылар, шуның белән бергә авыллар белән җитәкчелек итү дә үзәкләштерелде* ---. Мәйдан

**Эреләндерә башлау** Эреләндерергә тотыну. *Авыл Русиядә гомер-гомергә тәҗрибә басуын хәтерләтеп килә: аны я бөтенләй оныталар, я эреләндерә башлыйлар, я кабат вакларга-бүлгәләргә тотыналар.* Ватаным Татарстан

**Эреләндереп бетерү** Барысын да эреләндерү. *Бу елларда кайбер районнарны кушып, эреләндереп бетергәннәр иде инде.* Х.Гатина

**ЭРЕЛӘНҮ** *ф.* 1) Үсеп, бер-берсенә кушылып һ.б.ш. рәвештә күләмгә зуррак булып китү; зураю. *Тора-бара агачлар эреләнде, юл начарланды ---.* С.Шәрипов. *Казандагы «төркемнәр» арасында эреләнү тәмамланып килә, кечкенәрәк, көчсезрәк төркемнәрне «зурлар» күптән йотып бетерделәр диярлек.* Х.Ширмән

2) *күч.* Масаю, тәкәбберләнү, үзен үзе зурга кую. *Ул – мәҗлес хуҗасы һәм зур бер институтның ректоры, әмма иң гаҗәбе: аңарда шушы өстенлеге белән һичбер төрле эреләнү дә, масаю да юк.* Ә.Еники. – *Ә сине күргән дә юк. Эреләнде бервү, – диде Кәнзел, авызын тутырып тәмәкесен суырды да Талип карап торган якка өреп җибәрде.* М.Хәбибуллин

**Эреләнә бару** Акрынлап, аз-азлап эреләнү. *Якынайган саен, кабер ташлары да эреләнә барды.* Ф.Җамалетдинова. *Сунарчы түйралар белән капланган сыртка күтәрелде, күтәрелгән саен, агачлар эреләнә барды ---.* Ә.Әминов

**Эреләнә башлау** Эреләнергә тотыну; эреләнү билгеләре сизелү. *Башта алар һава торышы турында сөйләштеләр. Гадәттә, өлкәннәрнең сүз җебе шуннан эреләнә башлый.* Н.Гыйматдинова. *Иркәли-иркәли бозып та бетердек бугай инде үзен. Эреләнә башлады.* Л.Ихсанова

**Эреләнә төшү** Бераз эреләнү; тагы да эреләнү. *Мин, бераз эреләнә төшкән сымак, үземнең «Төхфәтелмөлек» һәм «Гайнелгыйлем» укуымны әйткәч, алар аптыраша төштеләр.* М.Гафури. *Эреләнә төшкән яңгыр тамчылары күлдәвеккә төшкәндә, су өстендә үтәкүренмәле куыклар хасил була да тетеләп юкка чыга.* А.Вергазов

**Эреләнеп алу** Кыска вакытка, азга гына, бераз эреләнү. *Кем икәнлеге җәһәт исенә төшеп, Салих эреләнеп алырга булды.* Т.Галиуллин

**Эреләнеп йөрү** Һаман, гел эреләнү. *Бүген әле Габдулла бөтенләй эреләнеп йөри.* Һ.Такташ

**Эреләнеп китү** Тиз арада, көтелмәгәндә, сизелерлек эреләнү. – *Тә-тә-тә!.. – дип куйды кайсыдыр. – Бу бүген бәрәңгенең зуррагын ашаган, ахры, бик эреләнеп киткән, – диде.* М.Хәсәнов. *Тәбәнәк кенә үрләр дә биегәя башлады, юл кантарлары да эреләнеп китте.* М.Юныс

**Эреләнеп тору** Һәрвакыт, бертуктаусыз эреләнү; әле, хәзерге моментта эреләнү. *Разия апа да эреләнеп тормады: һәркемгә исеме белән эндәште, һәркемнең хәлен-әхвәлен сорашты ---.* Н.Фәттах. *Ул үзенә охшаган да, шул ук вакытта эреләнеп торуы белән гаҗәп көлке дә иде.* М.Маликова

**ЭРЕЛӘҮ** *ф.* 1) Бергә кушып эрерәк итү, эрерәк ясау

2) Акчаны зурга, эрегә алыштыру; *кирес:* **ваклау**

**Эреләп бетерү** Барысын да эреләү

**ЭРЕЛЕ-ВАКЛЫ** *с.* 1) Төрле зурлыктагы, кайсы эре, кайсы вак, катнаш, аралаш. *Олауларның һәркайсында сандыклар, олы-олы әрҗәләр, төйнәп салынган урын-җирләр, иләк-чиләкләр, савыт-сабалар, эреле-ваклы төеннәр, чүпрәк-чапраклар.* М.Хәсәнов

2) Олысы да, кечесе дә булган, төрле яштәге. *Әни күчтәнәчләрен ала да эреле-ваклы балалар каршысына килеп баса.* Г.Бәширов. --- *урман буендагы иңкүлектә эреле-ваклы малайлар ыгы-зыгы килә.* Ф.Шәфигуллин

**ЭРЕЛЕК** *и.* 1) Эре булу үзенчәлеге. *Мичуринга үзенә чит ил сортларыннан җимешләренең эрелеген һәм яхшы тәм сыйфатларын, ә җирле сортлардан суыкка чыдамлылыкны күчереп алган чәчкеннәрне сайлап алырга кирәк була.* Дарвинизм нигезләре

2) Берәр нәрсәнең зурлыгы, күләме. *Бәлеш эченә дигән итне юганнан соң, сөякләреннән аерып, кузы чикләвеге эрелегендә турыйлар ---.* Халык ашлары

3) *күч.* Масаючанлык, тәкәбберлек, һавалылык. *Шулай да ул, берничә минутка, калыбыннан чыккандай, тәкәббер эрелеген онытып --- минем йөрәгемне дулкынланып кысылырга мәҗбүр иткән бер талпыну ясап ташлады.* Ә.Еники. *Тарихчы – күркә! Андагы горур кыяфәт, андагы каш җыерулар, бугаз уйнатып төрле тавышлар чыгарулар, эрелек!* М.Мәһдиев

**ЭРЕМӘ** *и.* Каты яки сыек матдәне суда яки башка сыекчада эретүдән барлыкка килгән масса; *русчасы:* **раствор**. *Варфоломей «Гүзәллек» фотоательесына мастер ярдәмчесе булып урнашты. Аңа эремәләр ясау, яктырту, чират көтүчеләргә хезмәт күрсәтү --- йөкләнде.* А.Мифтахетдинов. *Бер рюмкада – туендырылган шикәр эремәсе, икенчесендә туендырылган тоз эремәсе әзерләгез.* Кызыклы психология. *Диссоциация нәтиҗәсендә эремәдә электр үткәрүче ионнар хасил була.* Физика

**ЭРЕМЧЕК** *и.* Әчегән сөтне җылытып, суын аерганнан соң хасил була торган бөртекле ашамлык. *Көн уртасында якындагы кибеттән гадәттәгечә бер кап эремчек һәм каймак алып кайтып килешем.* А.Тимергалин. *Пешкән әйберләр, сохари, бер банка атланмай, бераз эремчек әзерләп, Мөнирә Актаныш төрмәсе янына килде.* Я.Шәфыйков

**ЭРЕМЧЕКЛЕ** *с.* Эремчеге булган, эремчек кушып, катнаштырып әзерләнгән. *Ул арада чиләк эчендәге эремчекле май чыжылдый да башлады.* Г.Галиев. *Моннан тыш әле уылдыклы бутерброд, яшел борчаклы бутерброд, эремчекле бутерброд, алмалы бутербродлар бар.* Матур буласың килсә

**ЭРЕН** *и.* 1) Организмдагы йомшак тукымалар ялкынганда барлыкка килә торган куе саргылт яки яшькелт төстәге куерык; үлек. *Кыяфәте куркыныч иде күршенең: шешенке күз кырыйларына эрен*

*укмашкан, иреннәре бер-берсенә ябышып каткан.* Р.Зәйдулла. *1936 елда үпкәсенә ясалган операциядән соң, Галимҗанның хәле яхшыра башлый, үпкәсендә эрен хасил булу кими ---.* З.Зәйнуллин

2) *диал.* Шеш, чуан

◊ **Эрен җыю** Эренләп шешү

**ЭРЕНЛӘ́Ү** *ф.* Шешкән, җәрәхәтләнгән урында эрен, үлек барлыкка килү. *Илшат, әтисенең тавышыннан уянып, эренләгән күзләрен угалады.* Р.Зәйдулла. *Яра төзәлмәде. Сасы ис чыгарып эренләде, зурайганнан-зурайды, врачлар арасында тагын аякны кисү турында сүзләр чыга башлады.* З.Зәйнуллин

**Эренләп бетү** Нык эренләү. *Айга якын елаган да елаган малкай, күзләре эренләп беткән.* Д.Гайнетдинова. *Күзләре эренләп, кысылып беткән, --- ниндидер бер сукбай белән Мәтли Хәбибулласы кибет артындагы калкулыкта --- өченче шешәне төпләп килләр.* Г.Сәгыйров

**Эренләп тору** Даими, әледән-әле яки хәзерге моментта эренләү. *Балтыр сөягендәге иске ярасы ачылган, эренләп, сүлләнеп тора ---.* Х.Камалов. *Аның ике күзе дә кызарган, алар туктаусыз эренләп тора.* Г.Бәширов

**Эренләп чыгу** Эрен барлыкка килү. *Микәйнең авызыннан сулар килде, тамак төбе янды, күзләре эренләп чыкты.* Р.Мөхәммәдиев

**Эренли башлау** Эренләргә тотыну. *Атна үтүгә, аякның төсе үзгәреп, шеше кимеп, җәрәхәт эренли башлады.* З.Зәйнуллин. *Бичараның инде берничә урында тәне дә сыдырылып, эренли башлаган.* Безнең гәҗит

**ЭРЕНЛЕ** *с.* Эрене булган, үлекләгән. *Укол салганнан соң --- кайсы сыерның күзе эренле булса, шунысы чирле – үпкә авырулы.* Х.Камалов. *Зөлфәтнең күзе эренле, бите шапшак, ирене суелган иде.* Н.Гыйматдинова

**ЭРЕСЫМАКЛАНУ** *ф. сөйл. к.* **эреләнү** (*2 мәгъ.*). *Аерата Вәсим эресымаклана иде: имеш, аның гигант төзелештә тотынмаганы-актармаганы инде бик аз калган ---.* Э.Касыймов

**ЭРЕТЕ́П ЯБЫШТЫРУ** *ф.* Металларны югары температура ярдәмендә кыздырып ябыштыру. *Минем участокта эретеп ябыштыру эшләре бар.* Х.Камалов. *Электр дугасы металларны эретеп ябыштыру һәм кисү өчен киң кулланыла.* Физика

**ЭРЕТЕ́П ЯБЫШТЫРУЧЫ** *и.* Эретеп ябыштыру белгече. *Минәхәт – эретеп ябыштыручы, без килеп җиткәндә эшендә иде.* Г.Сәгыйров. *Кеше арасында сүзе дә үткән, эшкә дә уңган – кулыннан килмәгән һөнәре булмаган: ул токарь да, эретеп ябыштыручы да, механик та, балта остасы да, пыяла-чы да...* Ә.Салах

**ЭРЕТКЕЧ** *и.* **1.** Нинди дә булса икенче матдәне эретергә сәләтле матдә. *Катнашмага эреткеч өстәү*

**2.** *с. мәгъ. күч.* 1) Эретә торган. *Кабина пыялаларына һәм калак-канатларына боз эреткеч җайланмалар куелган.* Р.Ибраһимов

2) *күч.* Яхшы мөнәсәбәтле, күңелгә керә торган, җылы, ягымлы. *Уфага килердән алда йөрәкләрне эреткеч җылы хатларында ул, гадәттә, шундый юллар язып җибәрә торган иде ---.* Ш.Биккол. *Әнисе плитә янында булаша иде. – Кайттыңмы, кызым, – диде ул, җан эреткеч ягымлылык белән.* М.Кәбиров

**ЭРЕТМӘ** *и.* Ике яки берничә каты җисемне, аеруча металларны кушып эретеп ясалган металл үзлекле коелма; *русчасы*: **сплав**. *Безнең заводта бит бронза эретү технологиясе һәйкәл кою өчен көйләнмәгән. Бу эретмәне алу өчен, Госснаб заводларга аның һәр килограммын төгәл үлчәп кенә бирә.* Г.Галиева. *Казанны кою өчен киткән эретмәдә тимер, цинк, кургашын, аккургаш, бакыр, көмеш һәм алтын да бар.* А.Тимергалин

**ЭРЕТҮ** *ф.* 1) Каты, кристаллик төзелешле матдәне, җисемне сыек халәткә китерү. *Металлургия комбинатында, домнада тимер эреттем мин шушы кулларым белән...* Р. Мөхәммәдиев. *Минзәләдәге офицерлар мәктәбе курсантлары пивзавод янындагы полигонда пистолетлардан, автоматлардан атып, өйрәнүләрдән кайтып киткәч, зоотехникум малайлары килеп, кызыл балчык арасыннан пуляларны җыеп кайталар да, кургашын эретеп, ядрә ясыйлар.* Р.Хәбибуллина

2) Түбән температураларда кристаллаша, туңа торган матдәләрне югары температура ярдәмендә сыекча хәленә күчерү. *Чишенми-нитми генә, тәрәзә бозын эретеп, урамга карый башлый.* А.Гыйләҗев. *Кояш көн саен югарырак күтәрелеп, урман эчендә генә калган карны да эретеп бетерә язды.* И.Хуҗин

3) Салкында калып каткан, туң әйберне йомшак хәлгә китерү, җебетү. *Харап уңайлы ул мич. Әминәсе алып кайтып биргәч, башта өйрәнә алмый интеккән иде, хәзер ит эретергә булса да шуны кабыза, аш-боткасын да шуңарда гына җылытып ала.* Д.Булатова. *Катырылган казны эретеп тормасагыз да ярый.* Шәһри Казан. *Керләрне эретү. Җиләкләрне эретү*

4) Гадәттә тыгызрак, катырак хәлдә була торган матдәләрне, җылытып, йомшаграк, сыеграк хәлгә китерү. *Гел сутлы юеш балчык эчендә йөреп, аяк-куллар ярылып, чебиләп беткән, аны бетерү өчен туң майны эретеп майлаганда, майның ачыттыруы йөрәгемә төшкән иде.* Г.Камал. *--- күпмедер вакыт узгач, авылда яңа һөнәр барлыкка килде: сагыз эретү.* М.Мәһдиев

5) Металл, пластмасс һ.б. ясалган әйберне махсус яки ялгышлык белән кайнарга куеп, аның тулылыгын бозу, үзгәртү. *Бераздан бик ачы ис чыгуга самавыр янына йөгереп килсәк, мин самаварга су салырга оныткан икән – күз алдыбызда самавырны эреттек.* Һ.Идиятуллина

6) *сөйл. з-сыз* Һава торышы җылыга таба алмашынып, карлар, бозлар эри башлау. *Кояш нурын болыт капласа да, Яз язлыгын итә – эретә, Карлар бетеп, кара җир яшәреп, Сандугачлар сайрар көн җитә.* М.Гафури

7) *күч.* Кешедәге усаллык, кырыслык яки үпкә хисләрен юкка чыгару, йомшарту; кешене юаш, күндәм итү. *Сүзе белән кешене эретә.* Х.Камалов. *Синең кебек өч ирне, эретеп, балавыз иткән инде мин.* Ә.Баян. *Тыңласыннар өчен, ул туганнарына матур-матур сүзләр таба: «Тәти абыем», «Җылы бабам», «Йомшак әбием» дип эретә.* К.Тимбикова

◊ **Эреткән дә череткән** 1) Кемнең дә булса гайбәтен сату турында. *Бер көнне Нәгыймә абыстайга дөньяга килмәгән сүзләр сөйләп җибәргән. Мине бөтенләй эреткән дә череткән.* Г.Камал; 2) Эштән чыгарып сүгү, орышу турында

**Эретә бару** Торган саен ныграк эретү. *--- халыкны төрле тарафларга сузылган Казан урамнары үзенә суырып алып, сафларны сирәгәйтә, эретә бара иде.* Ф.Сафин. *Аның миллиятен чит мәдәният эчендә тоз кебек эретә бара.* М.Исхаков

**Эретә башлау** Эретергә тотыну. *--- Мансурның аңа төбәлгән күзләрендәге җылы нур Фәйрүзәнең җанында укмашкан әрнүне әкрен генә, сиздермичә генә эретә башлагандай тоела.* Р.Мулланурова. *Рәмзиянең атна буе, үз баласын караган кебек, яныннан китмичә утыруы Минһадыйның хатын-*

*кызларга булган бозлы карашын бераз эретә башлады.* Д.Гыйсметдинов

**Эретеп алу** Тиз генә эретү. *Балны кәрәздән аерып алу өчен, кәрәзле балны уртача гына эсселектәге мич эченә куеп, эретеп алганнар.* Р.Зарипов. *Атланмайны яки маргаринны җиңелчә генә эретеп алырга да шуңа лимон кабыгын вак угычтан уып салырга.* Ватаным Татарстан

**Эретеп бетерү** Барысын да эретү. *Иреннәре битенә ялкын бөркегәндәй итте, сулышны буды, өнне алды. Ул гүяки Ленизаны тәмам эретеп бетереп, ахырынача үзенеке итте.* М.Маликова. *Менә ичмасам, бу ис шифалы, менә ичмасам, бу ис организмдагы шыплап тулган тозларны эретеп бетерә, минәйтәм, валлаһи!* М.Шаһимәрдәнов

**Эретеп җибәрү** Кинәт эретү; бераз гына эретү. *Каты бәгырьле энесенең җанга якын сүзләре Әһмулланы эретеп җибәрде.* Б.Камалов. --- *Хәбир әрнүле үпкә белән Мәдинәнең күзләренә карый да алардан йөрәген җылытырлык, боек күңелен эретеп җибәрерлек очкыннар эзли.* Ш.Хөсәенов

**Эретеп кую** Алдан эретү; эрегән хәлгә китерү. *Караваты астыннан әллә нинди ак калайга эретеп куелган киң җилем такта килеп чыкты...* Г.Ибраһимов. *Әнисе кичтән изеп куйган ярты чиләк ачы камырны унбиш йомырка, бер кечерәк табак уылган эремчек салып ишләде, күп итеп сары май эретеп куйды ---.* Н.Көбәш

**Эретеп ташлау** Тиз арада эретү. *Баш китәрлек бәла булу ихтималы аларны тагы бергә бәйләде, арада булган аңлашылмауны эретеп ташлаган кебек итте.* Х.Камалов

**Эретеп тору** Һәрвакыт, бертуктаусыз эретү; әледән-әле, еш эретү. *Бер кар явып, бер эретеп торганга, җир өстенә ала-тилә ямаулыклар салынды.* С.Рафиков

**ЭРҖӘ** *и. сөйл. к.* **эрзя**. *Әнә шул кышта аның кырыена --- тирә-юньдә тереклек иткән мукшы, эрҗә, чуваш, ар, чирмеш ил-тарханнары килеп сыгындылар.* М.Хәбибуллин

**ЭРЗАЦ** *и. нем.* Нинди дә булса табигый нәрсәне алыштыра торган ясалма әйбер, алмаштыргыч; суррогат

**Э́РЗЯ** *и.* Мордва халкы составындагы ике этник төркемнең берсе (икенчесе – мукшы) һәм шул этник төркемнең бер вәкиле. *Паспортларына мордва дип язсалар да, бу халык бер-беренең телен аңламый торган эрзя һәм мукшылардан тора.* М.Әхмәтҗанов. *Эрзя һәм мукшылар, тау марилары һәм болын марилары булган бит.* Д.Исхаков

**ЭРИ́СТИКА** *и. гр. кит.* Бәхәсләшү, полемика сәнгате, моназара кылу сәнгате

**ЭРИТРОЦИТЛАР** *и. күпл. физиол.* Кислород белән углекислый газны үпкәләрдән тән тукымасына күчерү функциясен башкара һәм канның күп өлешен тәшкил итә торган, гемоглобинга бай кызыл кан тәнчекләре. *[Гомуми билирубин] нормадан артып китү гепатит, үт куыгында ташлар булганда, эритроцитлар җимерелгәндә күзәтелә.* Юлдаш

**ЭРКЕТ** *и. диал.* 1) Әчегән сөт

2) Эремчек

3) Эремчек суы

**ЭРЛӘГЕЧ** *и.* **1.** Эрләү өчен хезмәт итә торган механик яки электр җайланмасы. *Аннан кайткач, Ибраһим хезмәт артеленә керә һәм 1921 елның язына кадәр төрле эшләрдә була: сабын кайната, сумала куа, җеп эрләгечләр, чаңгылар ясый.* Фән һәм тел. *Чормалардан эрләгечләр, шәмдәлләр төште.* Кызыл таң

**2.** *с. мәгъ.* Эрли торган, эрләү өчен хезмәт итә торган. *Эрләгеч станок бу өч операцияне дә бер үк вакытта һәм өзлексез алып барырга мөмкинлек тудыра.* Юлдаш

**ЭРЛӘ́Ү** *ф.* Йон, сүс һ.б.ш.ны, бөтереп, җепкә әйләндерү. --- *солдаткалар кичләрен бер-берсен дәшеп, --- моңаеп йон эрләгән, --- елашып-җырлашып утыра торган кичләр иде.* М.Мәһдиев. *Фабрикада сүсне җеп итеп эрлиләр дә аннан тукыма эшлиләр.* Дөньяда ниләр бар?

**Эрләп алу** Тиз генә эрләү. *Кичә хәлифә факеллар яндырып үткәндә, шуның яктысында җеп эрләп алдым.* Гасырлар авазы

**Эрләп бетерү** Барысын да эрләү. *Әнә йонны эрләп бетер, кишерләрне казып алып урнаштыр, борчакларны аерып җыеп куй!* Әкият. *Җебемне, бер тормастан утырып, күптән түгел генә эрләп бетердем.* М.Фәйзи

**Эрләп карау** Булу-булмавын сынау өчен эрләү. *Каләмемне орчык итеп, җеп тә эрләп карадым.* Р.Харис. *Алар олылардан эшкә өйрәнәләр: орчыклардагы эрләнгән җепне йомгакка күчерәләр, үзләре җеп эрләп карыйлар.* Мифлар

**Эрләп кую** Алдан эрләү; тиз арада эрләү. *Әнинең кышлый эрләп куйган җепләре булган икән.* И.Гази. *Бибимәмдүдәне дә атасы --- алдан ук кисәтте: – Йоннарыңны эрләп куй, утырмада оек-бияләйләр бәйләп кайтырсың, – диде.* М.Әмирханов

**Эрләп тору** Хәзер, сөйләү моментында эрләү; һәрвакыт, гел эрләү. *Ул эрләп тора, мин йонны язып, әзер җептән бәйләп торам: бер ай эчендә 30 пар оекбаш бәйләдем.* Татарстан яшьләре

**ЭРЛӘҮЧЕ** *и.* Эрләү эшен башкаручы кеше. *Эрләүчеләр эрли, тукучылар тукый, тегүчеләр тегә, тиречеләр тире или.* Җ.Ильясов. *Туку комбинаты каршындагы училищеда эрләүче һөнәренә укый.* Р.Даутов

**Э́РЛИФТ** *и. ингл. тех.* Сыекчаны (мәс., скважинадан нефтьне) күтәртә торган пневматик күтәргеч

**ЭРМЕКЛӘНҮ** *ф. диал.* Көпшәкләнеп, ярмаланып тору; эрмекле хәлгә килү. *Алма пешә эрмекләнеп, Алма кебек кызлар күрсәм, Телем кала көрмәкләнеп...* Р.Низами

**Эрмекләнеп тору** Эрмекләнгән хәлдә булу. *Юан саплы ак гөмбәләр, өсләре лайлаланып, бүрек аслары сары май төсле эрмекләнеп торган сары гөмбәләр бер-бер артлы тезелешеп утыралар.* Сәхнә

**ЭРМЕКЛЕ** *с. диал.* Бөртекләнеп таралып торган, ярмалы (мәс., сары май, бал, бәрәңге). *Эрмекле бәрәңге ясмык күпертмәсе, сөт белән тәмле.* Сөембикә. *Бу яшелчә эрмекле һәм таралучан булган саен, аңарда файдасыз крахмалның шулкадәр күп икәнлеген күрсәтә.* Яшел Үзән

**ЭРМИТАЖ** *и. фр. иск.* 1) Шәһәр читендә күңел ачу, аулакта күрешү өчен төзелгән сарай яки йорт; парктагы павильон. --- *рус патшабикәсе Екатерина II әдәп белмәүче сарай хезмәтчеләрен Россия императоры сараенда эшләгән «эрмитаж уставы» кагыйдәләрен үтәргә мәҗбүр иткән.* Казан утлары

2) Санкт-Петербургта дөньяның иң зур сәнгать һәм тарихи-мәдәни музейларыннан берсе. *Эрмитаж, Рус музее, Смольный, Киров (Путилов) заводы, Кронштадт кебек тарихи урыннарда булдык.* М.Әмир

3) Мәскәүдә, Казанда һ.б. кайбер шәһәрләрдә бакча исеме. *Комклуб (Коммунистический клуб) хәзерге Щапов урамының үрге башындагы Эрмитаж бакчасында агач йортта урнашкан булган.* Һ.Такташ. *Фатир бүлгәндә, безгә дә тәрәзәләре Эрмитаж бакчасына карап торган йорттан өч бүлмәле фатир бирделәр.* Л.Ихсанова

**ЭРО́ЗИЯ** *и. лат.* 1) *геол.* Тау токымнарының, туфракның боз, агымсулар, җил һ.б. тәэсире белән юылуы, ашалуы. *Көтү болындагы үләнне генә түгел, куакларны, әрәмәләрне таптап юкка чыгара, яр буенда эрозия башлана.* Г.Бәширов. *Аннары ул полосаларны, туфрак эрозиясенә каршы көрәш өчен, дип утырту кирәк иде.* М.Мәһдиев

2) *тех.* Металл өслегенең газ яки сыеклык, шулай ук электр корылмасы тәэсире нәтиҗәсендә әкренләп җимерелүе, таркалуы

3) *мед.* Тән тиресе яки лайлалы тышча өслегенең җәрәхәтләнүе. *Лайлалы тышчаның зарарланган өлешендә эрозия башлана, ул кисеп-кисеп авырта, әчетә.* Сәламәтлек нигезләре. *Ашказаны язвалары, эрозияләр булганда, бер ай дәвамында, кырган чи бәрәңгене ярты стакан оеган сөт белән болгатып, ач карынга эчәләр.* Әлмәт таңнары

**Э́РОС** *и. гр.* 1) *к.* **эрот**. *Алар карашынча, дөньяда мәхәббәт алласы Эрос яши торган булган.* К.Гыйззәтов

2) *кит.* Җенси теләкләрнең уянуына юл ачкан көч; кайнар, дәртле мәхәббәт, шәһвәт

3) *астр.* Кече планеталарның берсе

**ЭРОТ** *и. гр.* Борынгы грек мифологиясендә мәхәббәт илаһы. *Борынгы грекларның мәхәббәт алласы Эрот сүзе әүвәлге формасында ир-ат булганга охшый.* Н.Фәттах

**ЭРОТИЗМ** *и. гр.* Көчле, еш кына чамадан тыш, җенси теләк, җенси дәртлелек. *Кыз күзләү, кыз урлау, гыйшык, кияүгә бару шикелле мәсьәләләргә кагылып, тыңларга җыелган кызларны шаяртып, комплиментлар әйтеп, аларның эротизм тойгыларын кытыклау – менә шушы мотив Нәүрүз бәетләрендә кызыл җеп булып сузылып бара.* Г.Рәхим

**ЭРОТИК** *с.* 1) Җенси үзенчәлекне чагылдырган; җенси хис уята, җәлеп итә торган. *– Гаҗәеп шәп итеп тегендәге чибәр кызларның сыннарын ясый. – Шәп дигәнең нәрсәне аңлата? – дип елмайды Габделнур. – Аңлыйсың инде: эротик кыяфәттә – шәрә килеш, – диде Гена, күз кысып.* Р.Кәрами

2) Эротика (*1 мәгъ.*) белән сугарылган; эротика жанрына (*2 мәгъ.*) караган. *Чапаев турында Ершов дигән режиссёр эротик фильм төшерә, дигән хәбәр бар.* Т.Миңнуллин

**ЭРО́ТИКА** *и. гр.* 1) Җенси хис; җенси теләк, шәһвәт. *Порнография, секс, эротика, наркотик кебек төшенчәләрнең исемен дә белмәгән бәхетле чак!* Р.Фәйзуллин. *Китап кибетендә без китаплар күрәбез икән, аның 90 проценты укырга яраклы түгел: алар төрле мавыктыргыч триллерлардан, маҗаралардан, эротиканы пропагандалаучы китаплардан тора.* Т.Миңнуллин

2) Гыйшык-мәхәббәткә багышланган, җенси мөнәсәбәтләрне чагылдырган сәнгать әсәрләре. *Гәрчә эротиканы да сәнгатьтән куып чыгару дөрес булмас иде.* Ә.Баян. *Пушкин шигырьләрен, ярсып, ятар алдыннан кызарынабүртенә укып чыккач, кызлар башка мондый кульязма эротиканы укымаска сөйләштеләр.* Х.Ширмән

**ЭРОТОМАН** *и. гр. кит.* Эротоманиягә бирелгән кеше, эротомания белән авыручы. *Илне экономик бөлгенлеккә төшергән алыпсатарларны, --- халыкның әхлакый кыйммәтләрен пычратып тәрәт иткән сатлык журналистларны, гомосексуалистларны, фахишәләрне, эротоманнарны, ---чиновникларны бер бауга бәйләп, көлләрен күккә очырса, иркен тын алыр бәндә ---.* К.Кара

**ЭРОТОМА́НИЯ** *и. гр. кит. мед.* Җенси хискә артык бирелгәнлектән гыйбарәт психик тайпылыш; авыру дәрәҗәсенә җиткән җенси дәртлелек

**ЭРУДИТ** *и. лат. кит.* Киң эрудициягә ия булган кеше, эрудицияле кеше. *Ул кул астындагы --- Кавиев кебек эрудитларга гына түгел, материаль байлыкларны тудыручы эшчеләргә дә кычкыра ---.* Ж.Рәхимов. *Дустым --- үтә дә укымышлы егет. Эрудит, белмәгән нәрсәсе юк.* А.Хәсәнов

**ЭРУДИ́ЦИЯ** *и. лат. кит.* Фәннең яки тормышның берәр өлкәсеннән яки күп өлкәләреннән киң хәбәрдарлык, тирән белемлелек, укымышлылык. *Мин, футбол, хоккей өлкәсендә шактый надан кеше булганлыктан, Хәмит аганың бу эрудициясеннән көнләшеп яши идем.* М.Мәһдиев. *Әле менә болай сөйләшеп торуыбыз үзе генә дә ми эшчәнлегенең югары дәрәҗәсен, ягъни эрудицияне күрсәтә торган конъюнктив фактор бит, әйеме?* Н.Мадьяров

**ЭРУДИ́ЦИЯЛЕ** *с.* Бик киң һәм тирән белемле, укымышлы, эрудициягә ия булган. *Искәндәрев кебек зур эрудицияле, культуралы кешеләрне төрмәдә нишләтәләр икән?* М.Мәһдиев. *Студентларның күбесе шәһәрдән булып, --- һәрьяклап өстен, эрудициялерәк иде.* Р.Кәрами

**ЭРҮ** *ф.* 1) Каты җисем югары температурада йомшару, сыекчага әйләнү; русчасы: **плавиться**. *Шәмдәлләрдә шәмнәр эреп акса да, Өметләрне еллар утка якса да, Тик син генә миңа якты истәлек.* Р.Шәрипов. *Аңын югалткан хәлдә аны күршеләре күреп ала, аның чалбары пыскып яна, нейлон күлмәге, эреп, тәненә ябышкан.* Р.Ибраһимов. *Пыяласыман халәтнең үзлекләре – төгәл эрү ноктасы булмау, гомогенлык һәм изотроплык.* Төзү материаллары

2) Түбән температурада туңган матдә җылылык тәэсирендә сыекчага әйләнү; *русчасы:* **таять**. *Көн шактый җылы. Төнлә белән яуган карлар эреп, Төхфәтнең җеназасын китергән кыеш арбаның балчыклы тәгәрмәчләреннән кар өстендә калган сызыклар бетә бара иделәр.* Ш.Камал. *[Рафинад:] Әби, мороженыең эри.* Т.Миңнуллин

3) Суга яки башка сыеклыкка салынган матдә шуның белән реакциягә кереп, шуны туендыру, билгеле үзлек бирү; *русчасы:* **растворяться**. *Шикәр комына 1 стакан су салып, шикәр эреп беткәнче утта кайнатыгыз.* Сөембикә. *1 стакан суда 2 чәй кашыгы тоз эретеп, шуңа чылатылган тампон белән көн саен битне һәм муенны сөртергә кирәк.* Мәдәни җомга

4) Юешләнеп туңган әйбер җылыда җебү, йомшару. *Кыш үткәреп, җәйгә чыккач, җир эрегәнне генә көткән төсле, кешеләр чәчүгә чыгар алдыннан, ул үлеп китте.* Ш.Камал. *Туңнан керткән керләр эрү*

5) Әчү. *Сөт эрегән* // Оешу, төерләнү, эремчеккә әйләнү. *Сөтнең өсте ябусыз торган, --- кайната гына башлаган идем, эреде дә төште.* М.Фәйзи

6) *күч.* Нәрсәнеңдер күләме бик тиз кимү; сизелмичә бетүгә бару. *Йорт салырга дигән акча эри. Запаслар эреп бетте*

7) *күч.* Билгеле халык яки төркем башка халык белән катнашып китеп, үзен югалту, йотылу, ассимиляцияләнү. *Чин тарихчылары аларның чин мохитендә эреп югалуларын да төркләр арасында сәяси-милли аң, үзара бердәмлек, татулык җитмәүдән килеп чыккан дип аңлаталар.* Т.Әйди. *Хәзәр халкы эреп югалу белән бергә, хәзәр теленең дә юкка чыгу процессы барган, нәтиҗәдә, бүгенгесе көндә әлеге тел үле дип санала.* Мирас

8) *күч.* Нәрсәнеңдер микъдары, концентрациясе, күләме бик аз булып, таралып, бик тиз юкка чыгу, көтелгән нәтиҗә бирмәү. *Без кертәсе акчалар андый зур төзелештә эреп кенә бетәчәк*

9) *куч.* Башка бик күп кешеләр яки предметлар арасында игътибардан, күздән югалу, табылмас хәлгә килү. *Инкогнито бара торган 3 нче класс пассажиры йөзләгән башка пассажирлар арасында эреп югалырга мөмкин.* И.Нуруллин

10) *куч.* Ераклашып, нәрсәнеңдер баштан контурлары, аннары үзе дә әкрен-әкрен күзгә күренмәс булу, әкренләп юкка чыгу. *Газизнең ягымлы йөзе, күз яшьләренең томанында тоныклана барып, акрын гына эри-эри күздән югала.* Г.Бәширов. *Еракта – Казан ягы, иксез-чиксез болыннар, әрәмәлекләр зәңгәр рәшә белән офыкка барып тоташа, эри.* М.Мәһдиев

11) *куч.* Бик тиз, сиздермичә качып китү. *Әле генә монда иде үзе, кай арада эреде* // Гомумән юк булу, юкка чыгу, югалу. *Нәтиҗә бөтенләй көтелмәгәнчә булды: элеккеге дус, шәфкатьле, игелекле, шатлыгын, кайгысын бергә уртаклашкан --- коллектив «эреде», юкка чыкты.* Т.Галиуллин. *Әйберемне шунда гына куйган идем, эреде*

12) *куч.* Нинди дә булса тәэсирләндерә торган нәрсә йогынтысында йомшару, ягымлылану, юашлану. *Аерылышканда кешенең күңеле тула, нервлары йомшый, бәгыре эри...* М.Мәһдиев. *Юләр инде без: мактауга эрибез, әзрәк тәнкыйть ишетсәк кырынаябыз.* Н.Гыйматдинова

13) *куч.* Рәхәтлеккә бирелү, ләззәтләнү; тынычланып, иркенәеп китү. *– Һай-һай-һай, Гарифә, бу кадәрле дә тәмле булыр икән чәең, тәмам эредем, – дип [Әхтәм бабай] --- урыныннан кузгалды.* Г.Шәрәфи

14) *куч.* Бик тирән йокыга талу; тиз йокыга китү; оюу, түнү. *Көне буе бәбәй күтәреп, аннан-моннан юнәткән әче катык, әйрән белән сабый җанын саклап йөреп арганмын, ятам да эрим.* А.Гыйләҗев

◊ **Эреп аккан** Гел зарланып торучы; уңмаган, җебегән, булдыксыз кеше турында. *Безгә Газизҗан белән, пример, ярый, без – олы кешеләр, ә сез нәрсә, эреп аккан шикелле анда ятасыз? Вагон тулы кызлар.* Г.Әпсәләмов. **Эреп калу** Каушау, югалып калу, нишләргә белмичә тору. *Егет бу мизгелдә эреп калды, аннары ирексездән, бөтен дәрте белән, кызны кысып кочаклады.* Т.Галиуллин

**Эреп бару** Булган берсе эрү; эрү алдында тору. *Беренче кар төшә җиргә, Төшә дә эреп бара.* Г.Афзал. *Чип-чиста күк йөзендә диңгезнең зәңгәр сызыгы эреп бара.* М.Вәлиева

**Эреп бетү** Тулысынча эрү, барысы да эрү. *Көн кояшлы, җылы, кар инде эреп беткән.* Т.Әйди. *Чын румнар кайда хәзер? Яулаган биләмәләрдән «мәңгелек калага» агылган чуар халык арасында алар әллә кайчан эреп беткән.* Р.Зәйнуллин

**Эреп җитү** *к.* **эреп бетү**. *Ләкин боз әле дә эреп җитмәгән.* Н.Фәттах. *Ботинкаларын бер-берсенә сугып куюыннан аның әле өшегән тәненең бозы эреп җитмәвен аңларга мөмкин иде.* Ф.Яхин

**Эреп калу** Эрегән хәлгә килү. *– Үтегез! Үт түрдән! – диде ул, аннан көчкә телен әйләндереп, – улым Рөстәм, – дип өстәде. Бу сүзләрдән Рөстәмнең күңеле бөтенләй эреп калды.* Г.Исхакова

**Эреп китү** Кинәт эрү, бик тиз эрү. *Ни булган Сабитка? Туганы белән күрешкәч, әз генә күңел бозы эреп китteме әллә?!* А.Гыйләҗев. *Менә мин аңа [иремә], бүләк итеп, бер шешә бик яхшы вино алып кайтам. Мин кайткач, эри дә китә ул.* М.Мәһдиев

**Эреп тору** Хәзер эрү; эрегән хәлдә булу. *Ата кеше, остабикәсенең күңелен күтәреп: – Ай-һай ла, сумсасы, сумсасы, авызда эреп тора, – дип мактап куя.* С.Поварисов. *[Хафизов:] – Ниһаять, без икәү генә, гүзәлем!.. – дип, ниндидер әрсез ашкыну белән, исерүдән эреп торган Венераны күтәреп алды...* З.Фәйзи

**Эреп төшү** *к.* **эреп чыгу**. *Мин, Сара апаның: «Әй уңмаган нәрсә: чәйнегем эреп төшкәндер инде!» – дип, трубканы куеп, кайдадыр китүеннән файдаланып, телефонистка кызга үзебезчә сүз куштым.* Ш.Биккол. *Кылычы кылычка тиюе була, тегеләрнең кылычлары эреп төшә.* М.Хәбибуллин

**Эреп чыгу** Эрегән хәлгә килү, тәмам эрү. *Алларындагы бәрәңгеләре суынган, самавырларының кайный-кайный суы бетеп, эреп чыккан.* Ф.Ярullин

**Эри бару** Акрынлап, эзлекле рәвештә эрү. *Әйләнә-тирәдәге бөтен нәрсәнең җиргә иңгән караңгылыкта эри барып, офык читенең дә шәмәхә төскә авышкан шушы мизгелендә картның тавышы аерата ачынулы яңгырады.* С.Шәмси. *Ул боз сөңгесе кебек әкрен-әкрен эри барганын тойды ---.* Х.Камалов

**Эри башлау** Эрергә тотыну. *Шушы ерып чыкмаслык уйларга чумып утырган арада, җәйге кыска төн, тәмам сыекланып, таң яктылыгында эри дә башлады.* М.Юныс. *Хәзер кар әкренләп эри башлады.* М.Рәфыйков

**Эри төшү** Аз гына эрү; тагы да күбрәк эрү. *Җил ызбаны селкетми иде инде, тик тәрәзә пыяласында эри төшкән боз кисәкләре генә чытырдап куйгалыйлар иде.* В.Астафьев

**Эри язу** Чак кына эреми калу. *Кулдан кулга йөреп таушалмаган беркатлы кызның инде эри язып куйган күңеле шуннан соң Хариска карата боз булып катты.* Г.Сабитов

**ЭРҮСҮ** *ф. сөйл.* Аз гына эри башлау, эрегән хәлгә килү, җепшекләнеп китү. *Дөп-дөп сулап, эрүсәгән карда тирән эз калдырып, трактор килеп җитте.* Г.Гобәй. *Агач кайрысы чак кына эрүсеп, кайры астындагы эреле-ваклы бөҗәкләр ныграк хәрәкәткә килә башладылармы, тукран иртәгә томшыгы авыртачагы белән исәпләшеп тормый.* Ф.Хөсни

**ЭСДЕК** *и. рус тар.* Социал-демократ. *Халыкчы, эсер, эсдек булып, үзара аз-маз бозылышып та алалар.* Г.Ибраһимов

**ЭСЕР** *и. рус* 1) *тар.* Россиядә 1901–1923 елларда социал-революционерлар партиясе әгъзасы (*социалист-революционер* сүзнең кыскартылмасы). *Әлек эсер булган кешеләрне ул вакытта барысын да диярлек, җыеп, төрмәгә утыртканнар, юк иткәннәр.* Р.Мостафин. *Галимҗан Ибраһимов озак еллар дәвамында социал-революционерлар, ягъни эсерлар партиясе платформасында тора.* Ә.Рәшит

2) «Справедливая Россия» сәяси партиясенең әгъзасы

**ЭСЕРЛЫК** *и.* Эсер булу. *[Дубасов:] Син – күптән эсерлыктан киткән кеше. Тәүбә итеп, төрмәдән чыгарылдың...* Р.Ишморат

**ЭСКА́ДРА** *и. фр.* 1) Бер үк яки төрле класс хәрби диңгез корабльләренең зур берләшмәсе. *1716 елны Изге Өмет борыны янындагы Ашханә култыгында Голландиянең 42 фрегаты бата. Эскадра белән 43 миллиард франклык алтын су асты патшалыгында кала.* М.Юныс. *Катерлар тавышы тынуга ук, Кавалевский эскадрасын кузгатты.* И.Низамов

2) Чит ил судноларында йөзүдә булган хәрби корабльләр берләшмәсе. *АКШның адмирал Ярмелл командалыгында «Аугуста» крейсеры һәм дүрт миноносец составындагы эскадра рейдта якорь ташлый.* М.Мәһдиев

3) Кайбер илләрнең хәрби һава көчләрендә самолёт һәм ракеталарның берләшмәсе

**ЭСКАДРИ́ЛЬЯ** *и. фр.* 1) Хәрби авиациядә самолётларның берничә звеносыннан торган берләшмә. *Ике ай ярым хәрби госпитальдә ятып чыккач, аңа [Рәхимгә] бөтен эскадрилья алдында --- «Батырлык өчен» медале тапшырдылар.* Ф.Шәфигуллин. *Башкортстан хезмәтчәннәре үзләренең шәхси маяларыннан хәрби самолёт эскадрильяләре төзүгә --- иганә керттеләр.* М.Гыйләҗев

2) Кайбер илләрдә ракета, зенит ракетасы подразделениесе

**ЭСКАДРОН** *и. фр.* 1) Кавалериянең 120–160 атлыдан торган, җәяүле гаскәрдәге ротага туры килә торган подразделениесе. *Дондагы казаклар, кабат йөзлекләргә, эскадроннарга берләшеп, колхоз идарәләрен, авыл советларын --- җимереп ташлаганнар ---.* В.Имамов. *Тәүлек эчендә йөз кылычлы эскадроным, сугыша-сугыша, кырык чакрым үтте.* Ю.Әминов

2) Кайбер илләрнең (мәс., Франциянең) армияләрендә танк һәм разведка подразделениесе

**ЭСКАЛА́ТОР** *и. лат.* Кешеләр менеп һәм төшеп йөрү өчен, өзлексез хәрәкәт итә торган конвейер рәвешендәге баскыч. *Метро поездларыннан чыккан халык белән бөтен эскалаторлар, керү һәм чыгу урыннары тулы.* Р.Мостафин. *Габделнурны тагын да гаҗәбрәк могҗиза көткән икән әле: ул, үзйөрешле баскыч – эскалатор белән җиде кат җир астына төшеп, метроны күрде ---.* Р.Кәрами

**ЭСКАЛА́ТОРЛЫ** *с.* Эскалаторы булган. *Мәскәүдә берьюлы өч лента – эскалаторлы «хәрәкәт итүче тротуар» төзү планлаштырылган.* М.Хәсәнов

**ЭСКАЛА́ЦИЯ** *и. ингл.* Нәрсәнең дә булса (мәс., бәхәс, конфликт, хәрби агрессиянең) эзлекле рәвештә үсә, киңәя бару күренеше. *Россиянең сугыш чукмарларына «халыкара терроризм» Алланың рәхмәте кебек булды, шуңа аркаланып, алар хәзер илне ашкынып коралланү, хәрби эскалация юлына яңадан кайтарып керттеләр.* З.Мифтахов. *«Ул, бу очракта халык хезмәтчесе буларак, республикадагы 1,5 миллион тирәсе булган рус этник төркеменең үзенчәлекләрен исәпкә алмады һәм биредә инде күптән өлгереп җиткән тел конфликтының эскалациясенә этәргеч бирде», – дип яза рус мәдәнияте җәмгыяте вәкилләре ---.* Шәһри Казан

**ЭСКАЛОП** *и. фр. кулин.* Дуңгыз, сарык, бозауның арт санындагы йомшак, майсыз җиреннән озынча телем итеп киселгән, кыздырып әзерләнгән ризык. *Ресторанда пешекче булып эшләүче бу хатын сумкасына бифштекслар, антрекот-эскалоплар, пирәшкиләр салмыйча кайтмый.* Ф.Баттал

**ЭСКАПА́ДА** *и. фр.* Экстравагант, сәер кыланыш

**ЭСКАПИЗМ** *и. ингл. кит.* Китап уку, күңелле нәрсәләр турында уйлау, хыяллану юлы белән, чынбарлыкта булган ямьсез, эчпошыргыч һ.б.ш. нәрсәләрдән качу, уйлап чыгарылган дөньяга китү, хыял дөньясына чуму

**ЭСКАРП** *и. фр. хәрби* 1) Хәрби нигытманың тышкы, дошманга караган ягындагы текә стена

2) Тигезсез ландшафтта, гадәттә елга ярлары һ.б.ш.да бик текә һәм биек стена рәвешендә ясала торган, танкка яки башка хәрби техникага каршы җир нигытмасы. *Эскарплар, таулар, полигоннар, Блиндажлар, буш гильзалар һәм чишмәләр Күзләремдә кушылып әйләнделәр.* А.Хәлим

**ЭСКӘК** *и.* **1.** Вак, тиз ватылучан һ.б.ш. әйберләрне кыстырып алу өчен, медицинада һәм техникада кулланыла торган кыскыч; пинцет. *Нигә еллар тимәгән кашларына эскәк тигезде, йөзенә мул итеп иннек-кершән ягынды.* Э.Касыймов. *Аңкавының, теленең пешкән тиреләрен эскәк белән тарткалап алганнан соң, Шәһрия Әнәснең авызына күп итеп каз мае сылады да өенә озатты.* Ф.Садриев

**2.** *с. мәгъ. күч.* Тиз эләктереп алучан, үткен. *Бер сержант ашыкмыйча гына киемнәргә тотынды. Аның эскәк күзләреннән бер генә җөй дә читтә калмый иде төсле.* Р.Зәйдулла

**ЭСКӘККОЙРЫК** *и. зоол.* Эскәккойрыклылар отрядыннан саклану һәм һөҗүм итү әгъзасы – корсакның очында келәшчәсыман үсентесе булган озын яссы гәүдәле бөҗәк; *русчасы*: **уховёртка**. *[Розаның] бутоннарын, чәчәкләрен һәм җимешләрен гади эскәккойрыклар, бронзаклар, җир җиләге һәм кура җиләге озынборыннары зарарлый.* Юлдаш

**ЭСКӘ́ККОЙРЫКЛЫЛАР** *и. зоол.* Корсак очында келәшчәсыман үсентеләре булган бөҗәкләр отряды; *русчасы:* **кожистокрылые**

**ЭСКӘКЛӘ́Ү** *ф.* 1) Эскәк белән кыстырып, эләктереп йолку. *Таняның эскәкләп нечкәртелгән кара кашлары, дугаланып, өска күтәрелде.* Ф.Латыйпов

2) *күч.* Бер дә калдырмыйча йолкып бетерү; бик нечкәләп утау. *Син анда үлән әсәре калдырырга тиеш түгел. Чалгы тотып чаба белмәсәң, хет эскәкләп җый.* Казан утлары. *Көне буе суган араларын эскәкләдек*

3) *күч.* Бер дә калдырмыйча, берәмтекләп җыю. --- *Хлебороб хахулларының әрсез, эре кортлары, тубал-тубал булып өерелеп, чәчкә күзләреннән бүгенге көннең соңгы балын эскәкләп җыя.* А.Хәлим

4) *күч.* Берәмтекләп, бик җентекләп өйрәнү, тикшерү, уку һ.б.ш. *Белемне үз ихтыярым белән эскәкләп чүпләдем.* Л.Гыймадиева

**Эскәкләп бетерү** Барысын да эскәкләү

**Эскәкләп кую** Алдан эскәкләнгән хәлгә китерү

**Эскәкләп тору** Даими, әледән-әле яки хәзерге вакытта эскәкләү

**ЭСКӘМИЯ** *и. рус* Терәкләргә утыртылган тактадан гыйбарәт гади утыргыч. *Мортаза --- иң элек йон эчле бияләен салып, мич буендагы эскәмия өстенә ыргытты.* М.Хәсәнов. *Торак бинасы каршысында үскән сирень куаклыгы астында аулак эскәмия бар иде.* М.Юныс

**ЭСКӘНҖӘ** *и. фар.* 1) *иск.* Төрле материалларны, предметларны кысып, басым белән тыгызлый торган җайланма; пресс

2) Эшкәртелә яки ясала торган предметны селкетмичә кысып тору өчен гади җайланма; тиски. *Остаханәсенә килеп керсәң, исең китәрлек: дивардагы киштәләрендә нинди генә ышкы, струк, чүкеч, эскәнҗә, --- тагын әллә ничаклы эш кораллары тезелешеп яткан булыр.* Р.Низамиев. *Бер якта, буйдан-буйга, эскәнҗә беркетелгән верстак тора.* М.Хәсәнов

3) *күч.* Кыен, авыр хәл; фаҗига, бәхетсезлек. *Тиздән эш тә бетәчәк. Назимов иркенрәк сулыш алды, күкрәген кысып торган эскәнҗә бушый төшкән кебек булды.* Г.Әпсәләмов. *Алар озак сөйләштеләр. --- Бу эскәнҗәдән ничек ансатрак ычкыну әмәлләрен эзләделәр.* Х.Камалов

4) *күч.* Изү, кысрыклау, золым; эксплуатация. *Кая карасаң, анда тентү, кая карасаң, анда арестлар, кая карасаң да – анда суд, төрмә, ссылка, каторга, үлем!.. Бөтен Русия эскәнҗәгә кысылды!* Г.Исхакый

**ЭСКӘТЕР** *и. рус* Аш өстәленә, табынга җәя торган җәймә, өстәл япмасы, ашъяулык. *Әнием бераз дәшми*

*утырды, кулы белән ашыкмыйча гына эскәтерне сыпыргалады ---*. Ә.Еники. *Сузан өстәл зал уртасында. Аңа ап-ак эскәтер ябылган.* А.Расих

**ЭСКВАЙР** *и. ингл.* 1) Урта гасырда Англиядә рыцарьның корал йөртүчесе; соңрак – иң түбән дворян титулының берсе

2) Англиядә һәм Америкада кайбер чиновникларның, адвокатларның, җәмәгать судьяларының хезмәт урындагы титуллары

3) Англиядә һәм Америкада ихтирамлы мөрәҗәгать итү формасы

**ЭСКЕРТ** *и. рус* Печәннән, саламнан яки көлтәләрдән махсус ысул белән салынган зур кибән. *Кырда уракчы хатыннар, көлтә бәйләүче җиңгиләр, чүмәлә һәм эскерт куючы абзыйлар --- пәйда булды.* Г.Ахунов. *Алтын, моңсу бер көз иде. Әбиләр чуагы, --- андасанда сузылып яткан алтын эскертләр күренә ---*. М.Мәһдиев

**ЭСКЕРТЛӘ́Ү** *ф.* Печәнне, саламны яки көлтәләрне эскерткә салу. *Башта без, өлкән класслар, куна-төнә борчак эскертләдек ---*. А.Гыйләҗев. *--- лапаска, эскертләп, хуш исле урман печәне һәм әле яшеллеген югалтмаган бәрәңге сабаклары өелгән.* Р.Кәрами

**Эскертләп бару** Берсен дә калдырмыйча рәттән эскертләү. *Дүрт бригада да саламны җыеп, пресслап, эскертләп баралар.* Ватаным Татарстан. *Азык әзерләүчеләр саламны җыеп эскертләп баралар.* Тәтеш таңнары

**Эскертләп бетерү** Эскертләү эшен тәмамлау; барысын да эскертләү. *--- ул елны актарылып иген уңды, көн коры чакта эскертләп бетердек.* Ә.Хәкимов

**Эскертләп кую** Эскертләнгән хәлгә китерү. *Күршеләре белән сөйләшеп, бергәләп алып кайтканнар, эскертләп куйганнар.* Йолдыз

**Эскертли башлау** Эскертләргә керешү

**ЭСКЕРТЧЕ** *и.* Эскерт куючы. *Эскертне тегe башкорт әрәмәлегенә сала башладылар бугай. --- Эскертчеләр әле анда пыр тузып эшләп яталардыр.* Ф.Яруллин

**ЭСКИЗ** *и. фр.* 1) Картинаның, рәсемнең баштагы караламасы. *Соңгы эскизы мондыйрак иде: су буенда ак чәчле карт скрипкада уйнап утыра ---*. Р.Мирхәйдәров. *Бераздан Даниял альбомны ябып, урынына илтеп куйды да хатын-кыз рәсеме эскизлары ясарга тотынды.* З.Фәйзи

2) Скульптура әсәренең кечерәйтелгән масштабтагы башлангыч үрнәге, макеты. *Җиңү һәйкәленең эскизы*

3) Әдәби, музыкаль әсәрләрнең тулысынча яки өлешчә башлангыч редакциясе. *Чөнки алар, шагыйрьнең [Дәрдемәнднең] 1929 елгы җыентыгында әйтелгәнчә, шагыйрьнең куен дәфтәрендәге эскиз-парчалар.* Н.Юзиев. *Шуңа күрә аның хикәясе зур бер романның эскизы хәлендә генә калган.* Ф.Галимуллин

4) Һәйкәл һ.б.ш.ны карап ясау өчен эшләнгән, вариант буларак тәкъдим ителгән әзер үрнәк рәсем. *Чаллыда, махсус эскиз белән, ак мәрмәрдән затлы таш ясаттык ---*. Т.Миңнуллин

5) Шунда төшерелгән предметларны ясау өчен кирәкле барлык мәгълүматлары, билгеләре булган һәм сызымның төп кагыйдәләрен исәпкә алып кулдан ясалган техник рәсем, план. *Мәрьям эскизга карады. Аның күз алдына планшеттагы эскиз түгел, ә чын шәһәр, моңарчы күрелмәгән гаҗәеп кала килеп басты.* М.Маликова. *Алгы яктагы кульман белән дистәләрчә сызымнар, планнар, эскизлар һәм төрле рәсемнәр дә каядыр җыеп куелды ---*. Р.Мирхәйдәров

**ЭСКИЗЛЫЛЫК** *и. кит.* Тулысынча тәмамланмаганлык, тиешенчә җиренә җиткереп эшләнмәгәнлек. *Автор бу әсәрен «лирик эскизлар» дип атаган. Күрәсең, ул үзе дә поэманың эскизлылыгын сизгәндер.* Г.Рәхим

**ЭСКИМО** *и. фр.* Шоколад белән капланган туңдырма; туңдырманың шул төре. *Минем әни эскимо ярата...* Сөембикә

**ЭСКИМОС** *и.* Теле эскимос-алеут семьялыгына караган, традицион шаманизм динен тота торган, башлыча Аляска, Гренландия, Чукоткада яшәгән җирле халыкларга абенак һәм атабаск индеецлары тарафыннан бирелгән гомуми атама һәм шул халыкларның бер вәкиле. *Людмилага риваятьләр җыярга әйтәсе иде, дип уйлады ул. Чукчаларныкын да, эскимосларныкын да.* А.Мифтахетдинов. *Удмурт, немец, эскимос, нивх, дойч һ.б. халыкларның исеме «кеше», «кешеләр», «чын кешеләр» дигән сүзләргә барып тоташа.* Эзләнүләр, уйланулар, табышлар

**ЭСКОРТ** *и. ит.* 1) Кемне дә булса саклау яки хөрмәт күрсәтү максаты белән озатып бара торган очкыч, кораб, мотоцикл яки хәрбиләр төркеме. *Вәт, гөнаһ шомлыгы... Элеккеге мичман эскорттан бүленеп калган – машинасы кабынмый!* К.Кәримов. *Диңгездә сәяхәт иткәндә, илчеләрне бернечә корабтан торган почётлы эскорт озата барган.* Сөембикә

2) *күч.* Берәр кешенең артыннан калмыйча тагылып йөрүче. *Урамда сине яклаган булып, өреп алдан бара – почётлы эскорт!* Ш.Галиев

3) *неол.* Ялда, командировкада һ.б. кыска вакытлы чарада ир кешене (яки хатын-кызны) озатып йөрү өчен, аңа гадәттә матур кыяфәтле пар табып, түләүле нигездә биреп тору хезмәте (фахишәлекнең өртелгән формасы). *Берара: «Яшьлегем-чибәрлегем бар, шулардан файдаланып калырга кирәк – эскорт хезмәтенә («калын кесәле» ирләргә төрле кичәләрдә пар булып бару) урнашам», – дип, сабырлыгыбызны сынарга керешә.* Сөембикә // Шундый хезмәт күрсәтүче кыз (яки егет)

**ЭСКУ́ДО** *и. порт.* Португалиядә акча берәмлеге

**ЭСКУЛАП** *и. лат. кит.* 1) Борынгы рим мифологиясендә, борынгы грек мифологиясендәге Асклепий кебек, авыруларны дәвалау илаһы. *Римлылар кайбер аллаларны борынгы греклардан да үзләштерәләр. Мәсәлән, табиблык алласы (Эскулап), көч һәм куәт алласы (Һеракл – Һеркулес) һ.б.* К.Гыйззәтов

2) *шаярт.* Табиб, врач, медик. *Корея сугышы вакытында --- ул [Уольф Демора] бернинди белеме булмаса да, --- зур бер корабта табиб вазифаларын үти. Ялганчы эскулапка монда бер диңгезченең эренләп шешкән тешен суырырга --- туры килә.* Юлдаш

**ЭСМИ́НЕЦ** *и. рус* Эскадра миноносецы. *Эсминецның өстендә, шөпшәләр шикелле, фашист самолётлары уйнаган. Ниһаять, аларның берсе бомбасын нәкъ эсминецның өстенә туры китергән.* М.Мәһдиев. *Эсминец безне торпедалап киткәч, без Эгей диңгезендәге бер кыяга чыгып, коткарырга судно килгәнче, өч тәүлек сусыз, азыксыз яттык.* М.Юныс

**ЭСПА́ДА** *и. исп.* 1) Испан кылычы; гомумән, озын туры йөзле кылычларның гомуми атамасы

2) Кайбер испан телле илләрдә корридада үгезгә соңгы булып шпага кадаучы

**ЭСПАДРОН** *и. исп.* 1) Фехтованиегә өйрәткәндә кулланыла торган тупыйк очлы кылыч

2) Шул кылычның хәзерге спорт ярышларында кулланыла торган төре

**ЭСПА́НДЕР** *и. лат. спорт* Кечерәк мускулларга физик күнегүләр ясаганда кулланыла торган резин яки пружинлы сыгылмалы спорт снаряды. *Егет шифоньерның аскы тартмасыннан гантельләр һәм эспандер тартып чыгарды.* Р.Кәрами. *Аспирантлар – кызык халык: шкафта сабын, мунчала, юылмаган кер; коньки, эспандер, гер, гантель идәндә аунап ята.* М.Мәһдиев

**ЭСПАНЬО́ЛКА** *и. фр.* Очлы кыска сакал

**ЭСПАРЦЕТ** *и. фр. биол.* Кузаклылар семьялыгыннан Европада, Төньяк Африкада һәм Көнбатыш Азиядә таралган, мал азыгы буларак файдаланыла торган баллы үсемлек

**ЭСПЕРАНТИСТ** *и. рус* Эсперанто телендә сөйләшүче һәм шул телне пропагандалау белән шөгыльләнүче кеше

**ЭСПЕРА́НТО** *и. фр.* 1897 елда Варшава табибы Л.Л.Заменгоф уйлап тапкан һәм интернациональ лексикага нигезләнгән, тел берәмлекләрен ясауда сүзьясагыч аффикслар зур роль уйнаган халыкара ясалма тел (грамматикасы агглютинация принцибында эшләнгән). *Химиклар сараенда хәтта эсперанто телен өйрәнү курслары ачып җибәрделәр булса кирәк.* Р.Миңнуллин

**ЭСПЛАНАДА** *и. фр.* 1) *хәрби* Крепость белән шәһәр арасында ачык урын, буш ара

2) Берәр зур бина алдындагы мәйдан

3) Уртасында аллеялы киң урам

**ЭССЕ** I *с.* **1.** 1) Югары температуралы; бик каты кызган. *Көннәр бик эссе булу аркасында, гадәттә, учреждениеләр иртәнге якта һәм көн сүрелә башлагач кына эшлиләр.* А.Расих. *Бик тә, бик тә эссе – чамасыз дәрәҗәдә эссе, коры килгән җәй иде ул...* М.Вәли

2) Тропик. *Океан тирәнлекләреннән алып биек тауларга, эссе чүлләрдән арктик бозлыкларга кадәр бөтен җирдә тере организмнар очрый.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы. *Чәй – көньяк үсемлеге, аңа эссе һәм дымлы климат кирәк.* Дөньяда ниләр бар?

3) Тән температурасы югары булган. *Синең тәнең бик эссе икән... Әллә авырыйсыңмы, Гөлйөзем?* Т.Гыйззәт. *– Ярар, бетсен ул, Равил, – диде җиңги, эссе йомшак куллары белән әле һаман мине кочаклаган килеш, – онытыйк без бүгенге хәлне, яме?!* В.Нуруллин

4) *диал.* Кайнар. *Зөһрә кызның эссе яшьләре төшүләре белән Айны көйдереп җибәргәннәр.* Әкият. *Күргәзмәгә куярдай матур итеп бөрелгән өчпочмакларын мичкә тыгуы була, эссе мич өсләрен куыра да ала.* Р.Мулланурова

**2.** *и. мәгъ.* 1) Көннең, һаваның югары температурасы; көннең кызулыгы. *Тәрәзә ягыннан дулкын-дулкын булып эссе бөркелә.* М.Хәсәнов. *Көндезге эссе башлангач, Чирмешәндә су кереп, тулай торакка кайтып ял итә торганнар иде.* Р.Айзатуллин

2) Кешенең тән җылылыгы дәрәҗәсе. *Берничә көн инде авырый ул. Өченче көнне дә эштән кайтканда температурасы утыз тугыздан арткан иде. Дарулар эчеп яткач, тән эссесе иртәнгә беткән иде.* М.Маликова

3) Ягылган мунчаның ташына су сипкәннән соң барлыкка килгән җылылык, пар, кызу. *Йончыла күкрәк җиңелчә моң белән, Эссесе беткән җылы мунча сыман.* Ш.Бабич. *Авылда вакытта шәһәр кешесе бик шәп ул: үземә кил, килсәң, телефоннан чылтырат, фәләнтөгән, диләр, син мунча ташына эссе өстәп, салкын сыра шешәсен ачкалап, бөкрәеп, ялангач йөгереп йөргәндә.* М.Мәһдиев

**3.** *хәб. мәгъ.* 1) Һава температурасының югары булуы турында. *Эссе. Ләкин уйларны тропик эсселеге дә җиңә алмый.* М.Юныс. *Җәй көне кояш астында шундый эссе: тиз генә кызынып алырга да, хәтта пешәргә дә мөмкин ---.* Дөньяда ниләр бар?

2) Кемнеңдер эсселекне тоюы турында. *Миңа эссе монда*

◊ **Эссе салу** Мунчада, эссесе чыксын өчен, ташка су сибү. *Айдаш баба мунчаның ишеген шар ачып куйды да, таш өстендәге капкачны алып, ике тапкыр эссе салды.* Р.Батулла. **Эссе кабу** *к.* **эссе сугу**. **Эссе сугу** Кояш кызуы тәэсирендә баш авыртып, температура күтәрелеп авыру. *Хәерниса тәтәйне җәйге кызу көнне ураза килеш урганда эссе сугып үтерде.* Н.Исәнбәт. **Эссе табага бастыру** Кемне дә булса бик каты орышу; тиргәү. [*Харис:*] *Бар, тыңламый кара аның сүзен... Эссе табага бастыра!..* Казан утлары. **Эссе табага басу** Бик кыен хәлгә калу, ни эшләргә белмәү, каушап калу. *Эшләгән җирләрендә әнкәләренең соңгы самавырына тиклем талап алып киткәннәрен ишеткәннәре юктыр! Фельетон басылып чыккач сикерешерләр, эссе табага басарлар әле!* А.Гыйләҗев. **Эссе тию** *к.* **эссу сугу**. *Беренчедән, ак төс кояш нурларын кире кайтарып, башны эссе тиюдән сакласа, икенчедән, ул һәрвакыт чиста була.* Шәһри Казан

**ЭССЕ** II *и. фр.* Берәр таррак темага, аерым мәсьәләгә багышланган, прозада язылган, кечкенә күләмле публицистика яки критика әсәре; шундый әсәрләр жанры. --- *Р.Кутуйның Салих Сәйдәшев белән очрашу турындагы бер дигән хикәясе һәм Туфан турындагы бик матур лирик эсселары минем хәтеремә кереп калды.* Р.Мостафин. *Бу эссе [М.Хәбибуллинның монголларның Болгар илен басып алуы турында] – комлыкка төшкән берничә тамчы су гына.* Т.Галиуллин

**ЭССЕИСТ** *и. фр.* Эссе язу остасы. *Камило Хосе Села – прозаик эссеист, сәяхәтче һәм нашир, лингвист һәм тарихчы, академик.* Мәйдан

**ЭССЕЛӘНҮ** *ф.* 1) Кызу, эссе хәлгә килү. *Көннәр эссeләнгәннән эсселәнә.* А.Расих

2) *сөйл.* Тәннең температурасы күтәрелү. *Ул арада Гөлкәйнең күзләрен йокы баса башлады. Салкын алай калтыратмый кебек, киресенчә, мунча ләүкәсендә утыргандай эсселәнде.* Х.Ширмән. *Бизгәк белән авырганда да нәкъ шулай була иде: башта әткәсе --- калтырый, дерелди башлый, аннан соң тиргә батканчы эсселәнә.* Г.Иделле

**Эсселәнә бару** Торган саен арта барып эсселәнү. *Йөрәгенә кайнарлык йөгерә дә йөгерә, каны һаман эсселәнә бара.* Ф.Яхин

**Эсселәнә башлау** Эсселәнергә тотыну. *– Аннан соң менә нәрсә минем күңелгә килә, – диде Мостафа. – Хәзер һавалар эсселәнә башлады инде.* Ш.Камал. *Кояш багана буе күтәрелеп, көн эсселәнә башлагач, бер кулына чиләк белән су күтәреп, икенче кулына тимер кружка тотып килде ул ---.* Т.Таһиров

**Эсселәнә төшү** Тагын да ныграк эсселәнү. *Ләкин һавада бөркүлек кимемәде, киресенчә, тагы да эсселәнә төшкән кебек булды.* М.Хәбибуллин

**Эсселәнеп бетү** Тәмам, бик нык эсселәнү. *Көн эссе дип үзләре белән су алганнар иде алуын, кунак ашы каракаршы, диештергәләп, ачык күңелле Нилүфәрне әле эсселәнеп бетмәгән яшел миллек әвене астында сакланган су белән сыйладылар.* Р.Рахман

**Эсселәнеп китү** Кинәт эсселәнү; сизелерлек эсселәнү. *Бүлмә, чыннан да,*

*эсселәнеп киткән төсле иде.* З.Фәтхетдинов. *Көннәрдән бер көнне һава бик тә эсселәнеп китте.* Ф.Яхин

**ЭССЕЛӘ́Ү** *ф.* Эссе, артык дымлы, бөркү һава тәэсирендә тирләү. *– Үзем эсселәдем, аякларым туңды, – диде Илһамия, диванга аякларын бөкләп утырып.* Г.Әпсәләмов. *Ул инде монда килеп кергәнче дә байтак кына йөгергән иде булса кирәк, аның, эсселәп, бит алмалары кызарган, әйтәсе сүзе бар кебек, авызы ачылып тора иде.* Л.Гыйззәтуллина

**Эсселәп алу** Берара, аз гына эсселәү. *Бер эсселәп алдым... җаннан суык үтте.* Л.Шәех

**Эсселәп бетү** Тәмам, бик нык эсселәү. *Уф, эсселәп беттем, калын мамык юрганымны көч-хәл белән өстән төшердем ---.* Г.Хәсәнов. *--- бәйрәм вакытында тирләп, эсселәп бетәсең.* Шәһри Казан

**Эсселәп йөрү** Шушы арада эсселәгән булу. *Бик эсселәп йөргән чагым булса, Җибәрмәгез куып котыпка.* И.Гыйләҗев

**Эсселәп китү** Кинәт эсселәү. *Эсселәп китсәм, майканы да салып тормастан, гөрс суга!* М.Әмир. *Байчурин дулкынланудан кинәт эсселәп китте, йөрәге кысылып-кысылып типте.* Т.Әйди

**Эсселәп тору** Вакытлыча эсселәү. *Әллә нәрсә, бик эсселәп торам мин бүген.* Ф.Хөсни

**Эссели башлау** Эсселәргә тотыну. *Башта бик каты туңып дер-дер калтыранган Назимов тора-бара эссели башлады.* Г.Әпсәләмов. *Мин эссели башладым, Кыш бабай!* Л.Лерон

**ЭССЕЛЕК** *и.* 1) *к.* **эссе** I **2.** (*2 мәгъ.*). *Төшлектә эсселек күләгә җирдә илле өч градуска җитте.* М.Юныс. *Малай карышмый иде инде. Аны пар, эсселек изрәтте, себерке иркәләде.* Ә.Гаффар

2) Кешенең тән җылылыгы күрсәткече югары булу, югары температура. *Сафия янында киңәеп утырган Фагыйлә Батталовадан мичтән бөркелгәндәй эсселек килә иде.* М.Маликова. *[Сара (кулын тотып):] Сездә эсселек бар. Төсегез дә киткән. Утырыгыз.* Р.Раскулова

**ЭССЕЛЕ́-СУЫКЛЫ БУЛУ** *ф.* Берәр көтелмәгән сүз, хәбәр, эш-гамәлдән кисәк дулкынлану, курку, аптырашта калу. *Ул, җитди генә итеп: – Хәтирә апа, сиңа ат бирмәскә куштылар, – диде. Хәтирәнең бөтен тәне эсселе-суыклы булып китте.* М.Әмир. *Марзияне култыклап алуым булды, бөтен җаным-тәнем үзенә бертөрле тетрәнү кичерде, әйтерсең лә аннан ток үтте, миңа эсселе-суыклы булып китте ---.* А.Расих

**ЭССЕЛЕ́-СУЫКЛЫ ИТҮ** *ф.* Кинәт көчле тәэсир итү, тетрәндерү, аптыраштa калдыру. *«Суфия түгел!» дигән уй Кыямны эсселе-суыклы итте.* И.Гази. *Рашатның көлүе аның бөтен тәнен эсселе-суыклы итте, бала йоннарын кабартты, тезләрен калтыратты.* Ф.Садриев

**ЭССЕ́НЦИЯ** *и. лат.* 1) Берәр матдәнең азык-төлек, дару җитештерүдә файдаланыла торган, кулланганда сыегайтыла торган көчле эремәсе. *Менә син конфет ашыйсың – ул конфетта да нефть бар, чөнки яңа пешкән җиләк-җимеш исе килеп торган эссенцияне нефть продуктларыннан эшлиләр.* Дөньяда ниләр бар? *Тар стаканга яхшылап юылган чи йомырканы кабыгы белән салалар, өстенә, күмелгәнче, 70 процентлы серкә эссенциясе агызалар һәм 12 көнгә караңгы урынга куялар.* Татарстан яшьләре

2) Парфюмериядә төрле үсемлек, чәчәк, җиләк-җимеш һ.б.ны спиртта төнәтеп ясалган хушбуй төре. *Башкалар утка җиде кисәк сандал агачы ыргыталар, эрегән май, һәртөрле хушбуйлар һәм эссенцияләр агызалар.* Ә.Рәшит

3) *күч. филос.* Нәрсәнең дә булса гомумиләштерелгән, кыскартып әйтелгән төп нигезе, асылы; сыгынты, квинтэссенция. *Роман-эссе бер тын белән утырып язылган әсәр түгел; ул – озак еллар җыелып килгән уй-фикерләрнең эссенциясе.* Казан утлары

**ЭСТАКА́ДА** *и. фр.* Юлларны югары күтәрү, җәяүле һәм транспорт агымнарын аеру, суднолар килеп туктау, йөк төяү-бушату һ.б. өчен салынган күперсыман корылма. *Ул [Василий] туп-туры котлован янына китте. Аска карады. Балта осталары агач эстакаданы ясап бетереп киләләр.* А.Гыйләҗев. *Ике участок булмас булуын, әмма фәкать җир асты коммуникацияләре һәм эстакадалар гына корулы аерым участок оештырырга кирәк булыр.* Р.Кәрами

**ЭСТАМП** *и. фр.* Нинди дә булса рәсемнең рәссам яки гравёр тарафыннан гравюрадан кәгазьгә төшерелгән нөсхәсе. *Элекке Венеция күренеше картинасына да яңа рам ясаттылар. Шуңа туры килә торган берничә эстамп та сатып алып элгәч, зур зал хәзерге заманга хас җиңел бер төскә керде.* Г.Әпсәләмов. *Пикассо иҗат гомерендә 14 мең полотно, 100 000 гравюра һәм эстамп, китапларга 34 000 иллюстрация ясаган!* М.Хуҗин

**ЭСТАФЕ́ТА** *и. фр.* 1) *тар.* Атлы йомышчылар белән йөртелә торган ашыгыч почта

2) *тар.* Шушы почта белән җибәрелгән яки алынган хәбәр, хат

3) *спорт* Һәрбер катнашучы билгеле дистанция үтеп, шартлы әйберне үз командасыннан икенче катнашучыга тапшыру тәртибендә бара торган йөгерү, йөзү һ.б. буенча команда ярышлары. *[Балаларның] эстафета дигән йомышсыз йөгерешләре, әллә нинди эш башкарган кебек рапорт бирүләре --- күңелләрен күтәрәме? Күтәрә.* Ә.Баян. *Спортсменнар таяк бирешеп йөгергәнне ничек атыйлар әле? --- Ә, әйе, эстафета!* М.Галиев

4) *спорт* Шундый ярышларда, билгеле бер араны үткәч, катнашучылар кулдан-кулга тапшыра торган таякчык

5) *күч.* Берәр эш-гамәл, гадәт, традиция бер буыннан икенче буынга күчү, дәвам итү күренеше. *Әйтерсең ул [С.Садыйкова] миңа шушы җыры аша халкыбызның моң эстафетасын тапшырды.* Х.Бигичев. *Нефть промышленносте коллективлары үзара ярдәмләшеп, җиңү эстафетасын иҗади рәвештә бер-берсенә тапшырып эш итәләр икән.* М.Хәсәнов

**ЭСТӘ́Ү** *ф. иск.* 1) Теләү, арзу итү. *Фирак эстәрме һичбер кемсә сәннән?* Г.Тукай. *Әлеге рум аксөяге аның [Атилланың] урдасында үсте, шуңа да түрекләрнең ни уйлаганын, ни эстәгәнен ерактан укый ---.* Р.Зәйнуллин

2) Әйбер бирүне, ни булса да эшләүне үтенү, сорау. *Балалар елап-елап теләнәләр, хәер эстиләр.* А.Расих. *--- зират капкасы төбендәге теләнчеләр, кулларын сузып, аннан хәер эстиләр.* Р.Батулла

3) Туплау, җыю (белем тур.). *Ахун хәзрәт Бохараи шәрифтә гыйлем эстәгән кеше иде.* З.Бигиев

4) Эзләү. *Егет-кызларның --- күбесе, белем-бәхет эстәп, шәһәргә китеп бара...* Х.Ширмән. *Гомер буе Солтан байлык эстәде.* Х.Сафина

5) Арттыру. *Хәтта Сталин бүләк иткән академияләр дә акрынлап көч туплап, фәнни үсеш юлына элегрәк аяк баскан аркадашларыннан үрнәк, ярдәм алаала, егәрләрен эстәделәр ---.* Т.Галиуллин

**ЭСТЕТ** *и. гр. кит.* 1) Гүзәллеккә табынучы, нәфислеккә баш июче. *Ислам*

*Әхмәтҗанов – эстет. Ул башкарган һәр эштән югары кимәлдәге зәвыклылык сизелеп тора.* М.Галиев. *Фатих Әмирхан! Зыялы, аксөяк. Фаҗигалы язмыш. Ул яшьли ике аяксыз кала. Тукайның гувернёры. Эстет. Гүзәл хикәяче. Драматург. Журналист, галим.* Р.Батулла

2) Эстетизм (*2 мәгъ.*) тарафдары

**ЭСТЕТИЗМ** *и. гр.* 1) Матурлыкка, гүзәллеккә, нәфислеккә бирелгәнлек; матурлыкка, нәфислеккә сизгерлек. *Сезнең алда «эстетизм тарафдары», ягъни гүзәллеккә табынучы.* Шәһри Казан

2) Сәнгатьтә идея эчтәлеген читкә кагып, тышкы матур формалар белән мавыгучанлык; эстетикада формализм. *Туташ, көлеп, моның эстетика Белән бәйләнешен күрсәтте. Көтмәгәндә егет шап тегеңә «Эстетизм» дигән пичәтне.* Ә.Фәйзи

**ЭСТЕ́ТИК** I *и. гр.* Сәнгать теориясен яхшы белүче кеше, эстетика белгече

**ЭСТЕ́ТИК** II *с.* 1) Эстетикага мөнәсәбәтле, эстетика турындагы. *Аның нечкә зәвыклылыгы, эстетик принципларының югары булуы бала чагыннан ук килә.* Ә.Айдарская. *Эстетик карашлар да тотемистик фикерләүләр белән үрелгән.* Г.Дәүләтшин

2) Сәнгатьтә һәм тормышта гүзәллекне, нәфислекне барлыкка китерү, аны аңлый, сизә белү белән бәйләнгән. *Иптәшләрең алдында тешеңне казып утырма, синең кыек-мыек тешләрең берәүдә дә эстетик хисләр уятмый.* А.Хәсәнов. *Биючеләрнең нәфис пластик хәрәкәтләре матур эстетик тойгылар, горурлык хисләре уята.* Р.Фәйзуллин

3) Тормышта яки сәнгатьтә нәфислек, гүзәллек йогынтысы белән туган. *Җыр исә, музыканың иң популяр, иң аңлаешлы жанры буларак, --- кадерле күңел ачу чарасы, эстетик, әхлакый тәрбия чарасы булып килә.* Г.Бәширов

**ЭСТЕ́ТИКА** *и. гр.* 1) Сәнгатьне, табигатьтәге, тормыштагы, иҗаттагы матурлык формаларын өйрәнә торган фәлсәфи тәгълимат; сәнгатьнең үсеш законнарын, аның идея эчтәлеген һәм формасын, җәмгыять һәм кеше тормышында урынын өйрәнә торган фән тармагы. *Мунчаның нәрсә икәнен белмәгән бетле Европа рыцарьлары --- Шәрык җирен канга батырырга барганда, Гарәбстанның дәүләт учреждениесенә писарь булып урнашу өчен генә дә математика, --- эстетика фәннәреннән имтихан тотарга кирәк булган.* М.Юныс. *Эстетика дәресендә Рузия Хаковна әйтте инде: «Күңелләрне куандырып торсын өчен, шулай аксыл яшел төскә буялганнар алар [тегү машиналары] ---».* А.Вергазов

2) Кемнең дә булса сәнгатькә булган карашлар системасы. *Шуңа күрә символлар системасы һәрчак милли эстетикага йөз тота.* Д.Заһидуллина. *Драма театры эстетикасының курчак театрына йогынтысына кагылышлы күпсанлы сораулардан берсен – тамашачы хакындагысын аерып алыйк.* Р.Игъламов

3) Нәрсәнең дә булса гүзәллеге, матурлыгы. *Йорт хайваны, ягъни культуралашкан дуңгыз, пычрак, сазда аунный, симез, эстетикасы юк, ә кыргый дуңгыз – кабан нинди?* Р.Батулла

**ЭСТЕТЛЫК** *и.* 1) Эстет булу. *Эстетлыгы әллә кайдан күренә*

2) *к.* **эстетизм**. *Дөрес, бик аз гына бер вакыт эчендә Муса декадентларча эстетлык чире белән авырып алды.* М.Максуд. *Менә шушы чиктән чыгып карaганда, Марсельнең иҗаты, бигрәк тә шигырьләре, эстетлык белән аерылып тора.* Т.Миңнуллин

**ЭСТОКА́ДА** *и. спорт* Фехтованиедә шпага, рапира, кылыч һ.б.ш. белән туры перпендикуляр сугу

**ЭСТОН** *и.* Фин-угор телләренең берсендә сөйләшкән, башлыча Эстониядә яшәгән халык атамасы һәм шул халыкның бер вәкиле. *--- урысчаны бер сүз белмәгән эстоннар да команданы һич ялгышусыз аңлыйлар.* А.Гыйләҗев. *Бер миллионлы эстон халкын милләт буларак үз телләрендә укытылган мәктәп һәм, бигрәк тә, югары уку йорты коткарып --- калды.* Т.Галиуллин

**ЭСТО́НИЯЛЕ** *и.* Эстониядә туган яки Эстониядә яшәгән кеше

**ЭСТОНЛЫ** *и. ялг. к.* **эстонияле**. *Мәскәүле Ной Борисович Окунь, гыжылдап, җирдән калкына алмый җәфаланганда, эстонлы Ансонс белән латыш Скуя картны култыклап алдылар.* А.Гыйләҗев

**ЭСТО́НЧА** *рәв.* **1.** 1) Эстон телендә. *--- күптән түгел мин Эстониядә булдым, андагы татарлар эстонча сиптерәләр генә, ә руслар өйрәнергә ашыкмый.* Т.Миңнуллин. *Валтон исә безнең ниятkә ни өчендер артык сөенмәде, хәтта кызын эстонча бераз кыздырып та алды шикелле.* Т.Әйди

2) Эстон халкындагыча. *Лилли Әминә апага, җепне җепкә эстонча ялгап, якорь сурәте төшерелгән кофта бәйләп бирә.* Т.Әйди

**2.** *с. мәгъ.* 1) Эстон телендәге. *Эстонча шигырь сөйләтү*

2) Эстон халкына караган, шуңа хас булганча. *Эстонча туй үткәрү*

**3.** *и. мәгъ.* Эстон теле. *Каалеп – эчкерсез зат, Төркестанга барып, үзбәк каләмдәшләрендә кунак булган, әсәрләрен эстончага тәрҗемә иткән.* Т.Әйди. *Эстончасы бик яхшы түгел*

**ЭСТРАГОН** *и. порт.* Оешмачәчәкләләр семьялыгыннан аштәмләткеч буларак үстерелә торган һәм эфир майларына бай булган күпьеллык үсемлек; иссез әрем, тархун. *Эстрагонның яфраклары хуш исле була.* Яшелчәчелек. *Республикада сирәк кенә кыргый хәлдә эстрагон әремен яки тархунны очратырга була.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**ЭСТРА́ДА** *и. фр.* 1) Артистлар, театр коллективлары, музыкантлар һ.б.ш. тамашачылар алдында чыгыш ясау өчен эшләнгән күтәренке мәйданчык, сәхнә. *Операда җырлау белән бергә, мин эстрада сәхнәләрендә дә җырладым ---.* Х.Мәҗитов

2) Җыр, бию, сәнгатьле сөйләү кебек популяр, күңел ачу характерындагы кече формаларны берләштергән сәхнә сәнгате төре. *Нәкъ шул секундта сәхнә идәненең ике почмагына сөяп куелган кара динамиклар дөбер-шатыр килеп тавыш куптаралар, эстрада ритмы яңгырый башлый.* М.Мәһдиев. *--- мин филармониянең бер бүлеге булган җыр һәм бию ансамблендә эшләдем, эстрада артистлары белән артык аралашмадым ---.* Р.Тимерханова

**ЭСТРОГЕН** *и. физиол.* Хатын-кыз җенес гормоннарының җыелма атамасы. *Кайбер органнарның эшчәнлеге кимесә һәм организмда бара торган процесслар аз гына бозылса да, эстроген күләме кимергә мөмкин.* Сөембикә. *Хатын-кызлардагы җенес гормоны – эстроген – чәч бөртегенең яшәү циклын арттыра.* Юлдаш

**ЭСТУА́РИЙ** *и. лат. геог.* Диңгезгә яки океанга койган елганың бүрәнкә формасында киңәеп торган тамагы. *Елганың тамагы дельта яки эстуарий рәвешендә булырга мөмкин*

**ЭСЭС** *и. рус* Фашистик Германия армиясенең өстенлекле махсус частьлары (Schutzstaffel – *каравыл отрядлары* сүзеннән кыскартылган); СС. *Күркә кыяфәтле эсэс офицеры, --- текәп карап әсирләр алдыннан бер узды да, борылып, калкурак гәүдәле өч әсиргә*

*ымлады.* Ш.Рәкыйпов. *Минем батальон тулы бер эсэс полкын юк итте.* З.Хәким

**ЭСЭСЧЫ** *и.* Эсэс частьларында хезмәт итүче. *Бухенвальд лагеренда, тоткыннарны талатыр өчен, эсэсчылар махсус этләр асрыйлар иде.* Г.Әпсәләмов. *Китегез, кит күз алдыннан, кайчы колаклы, бүредән усал этләр, ялтыравык итекле аякларын киң аерып баскан резин тукмаклы эсэсчылар ---!..* Ш.Рәкыйпов

**ЭТ** *и.* 1) Шул исемдәге семьялыкка караган, кеше тарафыннан аучылыкта, сакта һ.б. эшләрдә файдаланыла торган, бүрегә охшаш йорт хайваны. *Айсылуның аяк тавышын ишетеп булса кирәк, бозау хәтле бер эт амбардан капкага таба сузылган тимерчыбык буйлап өрә-өрә чаба башлады.* Г.Бәширов. *Этнең улавы Нигъмәтҗанның колагына килеп керү белән, ул әрнүдән һәм ыңгырашудан туктап, бераз тынып ятты.* Ә.Фәйзи

2) *куч.* Явыз кеше. *Барган булсаң, теге этләрнең кыланышларын караган, нәрсә сөйләшүләрен тыңлаган булыр идең.* Ш.Камал. *Әнә бит ничек авызын ерып, очраган саен берәр пычрак сүз атып үтә Кәрбек, алар Зиннурга, аннан да битәр Нуриягә ничек тәэсир итәсен белә ул эт.* Я.Зәнкиев

3) *куч. кимс.* Тиргәү сүзе буларак кулланыла. *Сәрви, елый-елый, ирен сүгәргә тотынды: – Карт эт, котырынды бит, егерме ел торган катыны ярамый башлады бит, балаларны да ятим итә бит.* Ф.Әмирхан

4) *куч. сөйл.* Булдыклы, җитез, чая һ.б.ш. кешегә карата хуплап, сокланып әйтелә. *Һәр ике як теләсә кая сибелде. Кайдан көч кергәндер, мин дә бер малай артыннан сыпырттым. Җитез икән, эт, шәп җилдерә.* Р.Зәйдулла

◊ **Эт авызына таяк тыгып йөрү** *к.* **эт куып йөрү**. *[Персидәтел] чалбарымның умырылган җирен күрсәткәч тә кызганмады. Йөрисең шунда балачага кебек, эт авызына таяк тыгып, ди.* Ф.Шәфигуллин. **Эт авызыннан сөяк тартып алу** Саран, комсыз, явыз кешедән әйбер алу яки яхшылык эшләтүнең кыен булуы турында. *--- бер тоткын теге чая бәндәнең полкташына: – Бар әле, служагың биргән күчтәнәчне сора, – дип сүз кузгатып караган иде дә, икенче тоткын каршы төште: – Йөрмә. Эт авызыннан сөяк тартып алалмассың.* Р.Кәрами. *– Егетләр, иптәшләр, – диде Иван. – Нигә шуңа ялынып вакланасыз? Ул безгә суның тамчысын да күрсәтәчәк түгел. Эт авызыннан сөяк кем алганы бар!* Ә.Галиев. **Эт азабы** Бик авыр, җәфалы эш, хәл. *Ә монда – ачлык, нужа, эт азабы.* К.Нәҗми. **Эт артына типсәң, аңа тия** Кадерсез, түбән кеше яки һәркайда тулып яткан нәрсә турында. **Эт ассаң муенына җитмәс** Озын буй үстереп, эшсез, бушка йөргән, игелексез, ялкау кеше турында. **Эт ашаган** Берәр эштә, берәр мәсьәләдә үтә сыналган, тәҗрибәле, күпне күргән. *Моның өчен Сталин кулында тәмам аңа буйсынган әллә ничә миллион коммунист бар – чистартуны да, агартуны да шулар алып баралар. Бу эштә алар, русчалап әйтсәк, эт ашаган халык...* Ә.Еники. **Эт ашаганчы бет ашасын** Мал-мөлкәтнең яки акчаның, яман кеше кулына кергәнче, юкка чыгуын әйбәтрәк күреп әйтү. **Эт ашамас** *к.* **эт яламас**. **Эт ашыйсын бет ашый** Акчаның, мал-мөлкәтнең тиешле кешегә, кирәкле урынга китмәвенә ачынып әйтү. **Эт әрсезе** Үтә әрсез, гарьсез (кеше тур.). *Теге кеше эт әрсезе бер нәмәстә булып чыкты.* Ш.Маннур. *– Әнә шундый инде ул [бабай], – дип, тагын тотынды теге апа. – Эт әрсезе.* Г.Нәбиуллин. **Эт баласы** Тиргәү, кимсетү сүзе буларак кулланыла; көчек. *Мин Сосновкага җиткәндә, син, эт баласы, теге дөньяга ычкынырсың.* А.Әхмәт. *Син гаепле, барысына да син гаепле, эт баласы!* Р.Габделхакова. **Эт – баш, сыер – аяк** Рәтсез, тәртипсез эш-хәл турында. *Карап кына бетерерсең Әмрикәдәге башбаштаклыкны! Эт – баш, сыер – аяк бит анда.* Ф.Шәфигуллин. *Аларда пединститутта эт – баш, сыер – аяк икән. Былтыргы эшне быел яңадан китереп биргән кешеләр дә бар, рәхәтләнеп яклыйлар.* К.Тимбикова. **Эт башына эркет түгелгән заман** Муллык-туклык вакыты, һәркемдә барлык булган заман. **Эт бәйләсәң – тормас** Начар, каралмаган, бик салкын йорт-җир турында. **Эт белә** *к.* **эт белсен**. **Эт белән мәче кебек (шикелле)** Дошманнарча, туктаусыз ызгышып-талашып яшәү турында. *Торулары – эт белән мәче кебек.* Т.Гыйззәт. *Бергә-бергә кеше арасына да чыкканыбыз юк. Яшибез шунда эт белән мәче шикелле.* Ә.Сафиуллин. **Эт белән эзләсәң дә таба алмассың** Кемне яки нәрсәне табуы кыен булуы турында. *[Швейконы] --- ротада күп вакыт эт белән эзләсәң дә таба алмассың.* С.Шәрипов. **Эт белән эт булу** Усал, начар холыклы кеше белән эш иткәндә үзен шуның кебек тоту турында. *Олы башын кече итеп, Нуретдинов белән бәхәсләшсенме, нигә эт белән эт булсын?* Т.Миңнуллин. **Эт белсен** Билгесез, белүче юк, белеп бетерерлек түгел. *Һаман хәбәрләре юк, эт белсен, нишләп яталар анда?* А.Таһиров. **Эт бетергесез** Бик күп, исәбе-хисабы юк. **Эт булганчы** Бик нык, соң дәрәҗәдә, арганчы, тәмам хәлдән тайганчы. *– Укудан бүленгәнемне хәтерләмим, – ди Фәрит абый. – Шулай да эт булганчы эшләп, тизрәк уку башланса иде, дип хыялланган чаклар аз булмады.* А.Галиәхмәтова. **Эт булсаң, урамнан кермәс идең** Урамда, биләмдә күп йөрүче кешегә карата әйтелә. **Эт булу** Бик нык ару, азап чигү. *Уф Алла, тәмам эт булганмын. Авыз ачар, тел кыймылдатырлык хәл калмаган.* Н.Әхмәдиев. *Көн буе бәрәңге казып, бәрәңге чыгарып эт булган, сәхнәдә дә янып биегән ике егет мендәргә баш төртү белән сеңделәр генә.* Х.Сарьян. **Эт булып** Бик нык, бик каты. *Фабрикада эшләүчеләрнең күпчелеге Татар Буасы авылыннан. Усал халык. Ир-егетләре канга батып сугышыр, хатын-кызлары эт булып талашыр иде.* Ф.Фәтхелислам. *[Исерекнең] әнә бит, эт булып пычранган киемендә дә, хатынының тиргәвендә дә һичбер йомышы юк.* Ш.Хөсәенов. **Эт дагалап йөрү** Эшсез йөрү, вакытны бушка уздыру. **Эт дисәң – йоны юк, адәм дисәң – коны юк** Җүнсез, рәтсез, файдасыз, буе-сыны белән дә, рухы белән дә бернинди уңай сыйфаты булмаган кешегә карата әйтелә. **Эт дисәң – койрыгы юк, сыер дисәң – мөгезе юк** *к.* **эт дисәң – йоны юк, адәм дисәң – коны юк**. **Эте дә баш, бете дә баш** Хуҗасызлык. **Этем бигә төртем би** Башлыкларга ялагайланып, куштанланып, алар арасына кысылып йөрү. **Этем дә белми** Беркем дә белми. **Этем дә күрми** *к.* **этем дә белми**. **Этем дә калмаган (юк)** Бер кеше дә, бер җан иясе дә юк. **Этем иркәсе** Иркәләнергә, үзен иркәләргә яратучы, бердәнбер булып кадерләнүче. *Мин – төпчек малай – үтә этем иркәсе.* Ф.Хөсни. **Этем калган** Кая да булса баруны кирәк тапмауны белдерә. **Этем кеше** Кирәкмәгәнгә тагылып, тыгылып йөрүче кешегә карата әйтелә. *Бер тагылса, тиз генә котыла алмыйсың, этем кеше дә инде.* Ю.Әминов. **Этем кушкан** Кем дә булса үз белдеге белән теләсә кая кысылып,

тыгылып йөреп, кирәкмәгән мәшәкать, борчу китереп чыгарганда, авыр хәлгә калганда әйтелә. **Этем саяк** Андамонда яшерен юлларда сугылып йөргән рәтсез кеше турында. **Этеннән талату** Үзе читтә калып, икенче кеше аша үч алу. *Монда калып, сезнең этләрегездән талатыр хәлем юк.* Г.Ибраһимов. **Эт ерып чыккысыз** Бик күп яки бик нык буталчык (эш-хәл тур.). **Эте юкка бүре** Хатыннарның яннарында ирләре булмаганда аларга кул салырга омтылучы иргә карата. **Эт җигү** 1) Михнәт-җәфа чигү; азап чигү; 2) Күп эшләү, ару-талу. **Эт җиктерү** 1) Азап, михнәт-җәфа чиктерү; 2) Күп эшләргә мәҗбүр итү. *[Илдус:] Күрсәтермен әле мин сиңа зимагурны. Институтны гына бетерим. Мин әле сиңа эт җиктерәм.* Д.Салихов. **Эт итеп** 1) Оятка калдырып, хурлап, кимсетеп (орышу, тиргәү тур.). *Зариф аңа тагын да якыная төште: – Караале, Мидхәт, --- кешене эт итеп ташлавыңа вөҗданың газапланмыймы?* М.Хәбибуллин. *Касыймны сүгүдән башлап, коммунистларны эт итеп тиргәп, улы Габдулла белән кызы Мәрьямгә килеп җитте.* Г.Толымбай. *Үзен бер эт итеп гәзиткә язсын әле шул исерекбашның!* Ә.Исхак; 2) Бик каты, бик нык (орышу, тиргәү тур.). *– Халыкка культура хезмәте күрсәтүдән баш тарткач, мәктәптән буранның очырырга кирәк! – дип, [Мостафа] Хәкимҗанны эт итеп сукте.* М.Мәһдиев. *Булат бәк тәмам чыгырыннан чыкты һәм шул сорау белән мөрәҗәгать иткән яһүдне эт итеп орышып ташлады.* М.Хәбибуллин; 3) Бик каты, бик нык, үтергәнче (кыйнау, тукмау тур.). *Үзен эт итеп кыйнап киткән булыр идем.* А.Шамов. *Бу юлы да нахак бәла Хөрти намусына тагыла. Аны янә, эт итеп тукмап, тереләй кабергә күмәләр.* С.Поварисов. *Ох, Дилә, тапсаммы, үзеңне эт итеп кисәм.* З.Кадыйрова. **Эт итү** 1) Бозу, җимерү. *Кердек бакчага, бастык түтәл янына. --- Әнекәйләрем генә!.. Эт иткәнбез түтәлне, карарлыгы да калмаган.* Г.Шәрәфи. *Чабабыз пыр туздырып, Бер-беребездән уздырып! Ярты сәгатьләп чапкач, Арып, әлсерәп беттек, Түтәлне дә «эт иттек».* Ф.Зыятдинова; 2) Нык керләтү, пычрату. *Быел язын, археологлар Казан Кремле астын казый башлаганнар, дип ишеткәч, дәрестән соң шунда барган иде. Өр-яңа курткасын эт итеп кайтып керде.* Л.Гыймадиева; 3) Нык тиргәү, сүгү, хурлау. *Дуслар, дими, кызлар, дими, Һаман мине кимсетә: Кулы белән тими үзе – Теле белән эт итә.* Ф.Тарханова; 4) Кыйнау, тукмау, тәпәләү. *--- әлеге чандыр хатын тегене умач итеп уып ташлый, чалт-чалт яңаклый, эт итә ---.* М.Мәһдиев; 5) Арыту, алҗыту, хәлсезләндерү. *Хәбирә --- Маннурга эндәште: – Кара әле, Маннур!.. Фермабызны шефлыкка алган икәнсең инде, давай, тагын ярдәм ит... Эт итә бит безне бу каһәр төшкән бидоннар...* М.Хәсәнов. **Эт йөргесез** Табигатьнең яңгырлы, буранлы, бозык вакыты турында. **Эт кадәр дә күрмәү** Кешегә түбәнсетеп карау. **Эт кадере дә булмау** Ихтирам, кадер бөтенләй булмау. *Эт кадере дә булмый иде ул студент аерган хатыннарга!* М.Маликова. **Эт кадерен калдырмау** Бик нык әрләү, тиргәү, хурлау. *Башта адәмне эт кадерен калдырмый газаплагансың да, инде гафу үтенәсең.* Г.Ибраһимов. **Эт каешы** 1) Әрсез, күпне күргән кеше; теләгенә ирешү өчен бернәрсәдән тайчанмый торган, үзенекен итүче. *Хатын да нужа күрде, мин дә нужа күрдем. Шулай да эт каешы кебек түздек ---.* Г.Толымбай. *Шушы эштә усалланып, эт каешына әйләнеп беткән кызлар аңардан көлделәр.* Г.Ахунов; 2) Сүз үтми, тәнкыйть тәэсир итми торган, үзсүзле кеше турында. *Ләкин эш каешы Фәтхерахманны оялту алай җиңел түгел иде.* Г.Әпсәләмов. *– Мин әйткәнчә – җиде сумнан. Әхмәдиев миңа озак кына карап торды да кулын селтәде: – Эт каешы икәнсең, ярар, син дигәнчә булсын!* Ә.Еники. **Эткә атланып куян куа** 1) Үткен кеше турында; 2) Киресенчә: җебегән, пешмәгән, булмаган кеше турында. **Эткә койрык тагу** Кирәкмәгән, мәгънәсез эш белән шөгыльләнү. **Эткә печән ашату** 1) Юк эш белән, файдасыз эш белән маташу; 2) Эшсез селкенеп йөрү, файдасызга вакыт уздыру. **Эткә печән чабып йөрү** *к.* **эткә печән ашату**. **Эткә салган сөяк** Эчеп-исереп яисә бик нык кыйнап ташланган кешегә карата әйтелә. **Эткә салсаң, эт иснәмәс** *к.* **эткә салсаң, эт яламас**. *Миннән артыграк кеше белән булса – бер хәл иде, эткә салсаң, эт иснәргә җирәнә торган нәрсә бит.* Н.Харисова. **Эткә салсаң, эт яламас** Бик ямьсез, үтә шыксыз (кеше тур.). **Эткә сөяк аткандай** Тупас итеп, игътибарсыз, илтифатсыз, дорфа рәвештә. **Эткә сөяк ташлау** Ришвәт бирү. *– Сез, Алексей Лукич, эткә сөяк ташлап котылмакчы буласыз. Мин мондый нәрсәгә бара алмыйм, – диде профессор, тыныч кына.* Г.Әпсәләмов. **Эткә типсәң, аңа тия** *к.* **эт артына типсәң, аңа тия**. **Эткә үлем тияме** Яман кешедән җиңел генә котылып булмау турында. **Эт кебек ару** *к.* **эт булу**. *[Шаяз] таң белән эшкә торып чаба, кич исә эт кебек арып кайта да үз ягына кереп ава.* Х.Камалов. *Юлда ул бик нык туңган һәм эт кебек арыган иде.* Н.Әхмәдиев. **Эт кешегә – эт теше** Усалга усал тору турында. **Эт койрыгы астына китү** Әрәм булу, юкка китү, җилгә очу. *– Син дә бит хрусталь дип авыз суы корытасың. Конфискация булса, әнә бар җыйганнарың эт койрыгы астына китә, – диде Вил.* Х.Камалов. **Эт койрыгын болгаганчы** Тиз арада, шунда ук. **Эт койрыгын кыркып йөрү** *к.* **эткә печән ашату**. **Эт койрыгыннан да төз** 1) Кәкрене төз дип дәгъва кылучыдан көлеп әйтү; 2) Акыллы, инсафлы булып кыланучыга карата. **Эт колагыннан талпан суыру** Бик мәшәкатьле эш турында. **Эт корсагына (эченә) сары май килешми** Яхшы, сыйфатлы, затлы ризыкның кадерен, кыйммәтен аңламаучыга карата әйтелә. *– Ярамаган татарга каз ите, – дип көлеп җибәрде, урындыкка чүмәште. – Эт корсагына сары май килешер микән, дип әйтүең түгелме?* Р.Кәрами. *Юк, эт корсагына сары май килешмәгән кебек үк, студент корсагына да май килешми.* Ф.Баттал. **Эт корсагына (эченә) суык су** Яланып, ялманып йөрүче әрсез кешене биздерү өчен әйтелә. **Эт котырса, төнгә табан** Юньсез кешенең вакытсыз бер эш башлавы, вакытсыз котырынуы турында. **Эт кояшы** 1) Якты булса да, җылысы булмаган кояшлы көн турында. *Хәтеремдә, ул иртәдә кояш аеруча нурлы, балкышлы иде. Офык артындагы язны да чамаларга, тоярга мөмкин инде. Мондый кояшны «эт кояшы» диләр. Үзе суык, үзе... Яп-якты!* Г.Гыйльманов; 2) Сирәк күренә торган нәрсә турында; 3) Төрлегә үзгәрә торган, тотрыклы булмаган нәрсә. *Безнең иише картларның сәламәтлеге тотрыклы түгел, эт кояшы белән бер ул, көненә кырыкка төрләнә.* Г.Тавлин. **Эт көне** Авыр, начар тормыш; башкалар кулына калып яшәү. *Үгез кебек угылың бар... Аны мәдрәсәгә җибәрәсең дә, мин монда эт көнендә йөрим.* Г.Ибраһимов. *[Мотаһирны] тамырың чересен дип, эт көненә*

*калдырдылар.* Р.Кәрами. **Эт көтү** Эшсезлектән ни кыланырга белмичә яшәү. **Эт көтүе** Артык күп булып җыелган кешеләргә карата хупламыйча әйтелә. *Бүгендә әнә эт көтүе халык җыелды, ә әңгәмәнең элә-тотанагы юк: килгәне бере Мәүлиханы мактаган була, Кәримәнең салпы ягына салам кыстыра.* А.Гыйләҗев. *Бина каршындагы тар урамда эт көтүе кебек халык, төрлесе төрле киемнән һәм төрле кыяфәттә.* З.Хөснияр. **Эт көтүе куып йөрү** *к.* **эт куып йөрү**. *Син әнә өйләндең, баһадир, ә мин һаман эт көтүе куып йөрим.* М.Хәбибуллин. **Эт көтүче** Эшсез вакыт уздырып йөргән яки файдасыз эш белән шөгыльләнгән кеше. *Әйе, бригадир, управляющий – шул ук көтүче, тик эт көтүчесе.* Н.Әхмәдиев. *Син ялгышмагансың, Әскәр, район газетасының әдәби сотруднигы эт көтүчесе белән бер.* З.Вәли. **Эт (куу)** *к.* **эт куып йөрү**. *Гафур, яле, кара тактага гына карап утыр әле. Урамга ашыкма. Өлгерерсең – монда сәгатьләр генә, урамда көннәр буе эт куарга мөмкин.* Ә.Баян. *Эт куарга бармыйм бит. Музыка язарга, акча эшләргә!* Н.Гаетбай. **Эт куып йөрү** Эшсез вакыт уздырып йөрү; юк эш артыннан мәгънәсезгә йөрү. *Аның каравы, мәктәптән качып, ашауны-эчүне онытып, көнозын эт куып йөргәнлеге өчен, кичен малайның үзенә җавап бирергә туры килде.* Ф.Хөсни. *Әти-әнигә рәхмәт: чәчрәп чыкмадылар, университетны ташлап китеп, әллә кай җәһәннәмнәрдә эт куып йөргән өчен әр-зар сүзләрен яудырмадылар ---.* А.Гыйләҗев. **Эт күңеле бер сөяк** «Кешенең күңеле булсын өчен күп кирәкми» мәгънәсендә. *– Ыхым-ыхым, – диде Майчан аксакал. – Оланнар, ыругдашлар! Утыз мең кеше безне аяктан җыкмас, Алмыш ханның кылычы – җыгар. Эт күңеле бер сөяк. Алсын да китсен!* Н.Фәттах. **Эт күргән мәче кебек** Күзләрен алартып караучы турында. **Эт күрмәгәнне күрү** Бик нык газап чигү. *Эт күрмәгәнне күрәдер Безнең башлар – түзәдер.* Җыр. *Киләчәк өчен яңадан эт күрмәгәннәрне дә күрергә ризамын, иптәш Мамалеев!* И.Юзеев. **Эт кыркып йөрү** *к.* **эт койрыгын кыркып йөрү**. **Этләргә танау сөртерлеге дә калмау** Тәмам бетерү, эштән чыгару турында. **Эт муенына энҗе муенса** Затлы бер нәрсәнең яки яхшы кешенең бик түбән, рәтсез, начар кешеләр кулына дучар булуына карата әйтелә. **Эт нәрсә** *к.* **этҗан**. *Бүлмәсенә кайтып кергәндә, ул Вәлүкне сүкте: «Я инде, эт нәрсә, кич ялга каршы очраган булса...»* А.Алиш. *Ә мин тегеңә күз кысам. Эт нәрсә икән үзе дә, барысын аңлады.* Г.Әпсәләмов. **Этнең дә күге** *к.* **этнең эте**. **Этнең эте** Үтә әрсез, әшәке кеше. *Ну, дуңгыз нәрсә соң үзе дә, этнең эте инде.* Г.Камал. **Этне (үз башына) симертү** 1) Яман кешегә азып-тузарга юл кую; 2) Баланы артык иркәләп үстереп аздыру, начар юлга басуына сәбәпче булу. **Эт оясына таяк тыгу** Усалларны үзенә каршы котырту, тагын да ярсыта төшү. **Эт өрдереп, кеше көлдереп йөрү** Үзен үзе мыскыл иттерерлек эшләр эшләү, кылану. **Эт өслэтеп йөрү** Эшсез, шөгыльсез йөрү. **Эт сугарып йөрү** *к.* **эт куып йөрү**. *Яшең --- яшькә җиткән, сакал-мыегың чыккан, болай эт сугарып йөрү җиткәндер инде сиңа.* А.Таһиров. *Беленков чыгып киткәч, егетләр шаулаша башладылар: «Нәрсә, ике атна буе эт сугарырга кушамы ул әллә?»* Г.Сабитов. **Эт талаган кебек** Әйбернең бик нык ерткаланып, чачакланып, телгәләнеп бетүе турында. *Кайсыларының киндердән суккан ыштан балаклары эт талаган кебек сүтелеп беткән, чабаталары тишек, кайсылары бөтенләй яланаяк.* В.Имамов. *Киемсалымның тәмам рәте киткән шул. Чалбарның тез башлары тишек. Гимнастёркасы эт талаган кебек, тәмам теткәләнгән хәлдә.* С.Лашманчы. **Эт талый дип, бет талый** Олы усалдан күрмәкче, кечкенә усалның да талавы, телләшүе. **Эт тә белә** Һәркемгә билгеле, бар кешегә дә мәгълүм. **Эт тә белми** Бөтенләй беркем белми. *Складыңда бер тонна уксустан башка берни дә юк, бетең дә юк синең, сине эт тә белми!* Х.Ибраһим. **Эт тә борын сузмаслык** Начар, буранлы, салкын (һава тур.). **Эт тә койрыклы булган** Кемнең дә булса үз табышына бик мактанган, һаваланган чагында әйтелә. **Эт тә күрмәү** Берәү дә, беркем дә күрмәү. *Көннәрдән бер көнне ул --- кызы белән киявенә никах укытып алды. Ярый, өйдә берәү дә юк чак иде, моны «этем дә» күрмәде...* Ә.Еники. **Эттән алып дуңгызга салу** *к.* **эттән алып эткә салу**. **Эттән алып эткә салу** Бик каты сүгү, тиргәү, хурлау. *– Әнисенең хәле ничек, бәбәе сихәтме, дүрт саны тигезме? – дип сорашмады партконференция делегаты, ата белән ананы эттән алып эткә салды.* А.Гыйләҗев. *Урыгымнан торалмый махмырлап яткан иртәләрдә, эттән алып эткә салып, ничә тапкыр үз-үземне әрләдем.* Г.Мөхәммәтшин. **Эттән ач, беттән ялангач** Тәмам ач-ялангач, юклык, нужа эчендә. *Тәндәге җанны саклаган булып, эттән ач, беттән ялангач яшибез инде шунда.* М.Галәү. **Эттән әрсез, алабайдан гарьсез (кадерсез)** Үтә битсез, ертлач, гарьсез кеше турында. **Эттән дә үтә, бездән дә** Авыр, михнәтле гомергә ачынып әйтү. **Эттән калган сөяктәй** Кадерсезгә калган кешеләр хакында. **Эттән күп** Бик күп һәм кирәксез нәрсә турында. *Булды юлда киртәләр, эттән күп иде дошманым ---.* Г.Кутуй. **Эттән сөяк артмау** Саран, комсыз кеше кулындагы малын ычкындырмау турында. *– Таҗылбанатка пенсия билгеләү мәсьәләсендә мин үз фикеремдә калам, – диде Харисов, беренче булып кузгала башлап. – Тик, ай-һай, эттән сөяк артыр микән?* М.Хәбибуллин. **Эттән туган (яралган)** Оятсыз, вөҗдансыз һ.б.ш. кешене тиргәп әйтү сүзе. *Сафи абзый: «Ах, эттән туган нәрсәләр!» – дип акырып җибәрде.* Г.Толымбай. *– Эттән туган! Сиңа ни җитми?! – Семагин сикереп торды һәм күтәрелеп килүче үсмергә яңадан сугарга әзерләнгән Михайловның кулыннан әләктереп алды.* Р.Кәрами. **Эттән – эт, беттән бет туа** Яманнан яман туа. **Эттән ярлы** Үтә дә ярлы. **Эт тә өрми, кеше дә сизми** Беркем дә сизми, күз-колактан яшерен. **Эт тә өрми, песи дә күрми** *к.* **эт тә өрми, кеше дә сизми**. **Эт тә тора, бет тә тора** Төрле кешеләрнең яшәү дәрәҗәсе, көнкүреше арасындагы төрлелек турында. **Эт тә юк** Берәү дә, беркем дә булмау. *Барып керсәм бухгалтерия ягына – эт тә юк, өстәлләрдә исәп-хисап кәгазьләре генә чәчелеп ята.* Ф.Шәфигуллин. *Кырда эт тә юк.* М.Мәһдиев. **Эт типкесендә (тибенгесендә)** Түбән, вак, усал кешеләр кулында кадерсез булып (яшәү, эшләү тур.). *Хатынына нинди җәза бирергә икән дип озак баш ватты: «Аерып җибәрергә! Йөрсен шунда эт типкесендә».* Ф.Яруллин. *Абыйсы Баязит эшне бик коры һәм кискен китереп куйды: – Минем эт типкесендә йөртелергә тиешле сеңлем юк!* Ш.Максудова. *Эт тибенгесендә тилмереп йөргән, үзе арыган, үзе беркемгә дә кирәкмәгән адәм баласы хәзер йомшак түшәк, кайнар кочакта ята ---.* Ф.Садриев. **Эт токымы** *к.* **эттән туган**.

*Аларга аптырап-аптырап карап торуымны күргән Игорь кенәз, бу хәлгә ачуы килеп, миңа кул ишарәсе ясады, ятарга кушты, ул да түгел, сүзгә күчеп: – И эт токымы! – дип сүгенде.* Ф.Яхин. *Яхшы чакта күзебездән югал, эт токымы!..* Г.Тавлин. **Эт тормышы** Начар, авыр тормыш. --- *берничә полкташым белән бергә әсирлеккә эләктек. Аннары инде лагерьдан лагерьга – эт тормышы башланды.* М.Галиев. *Куркытма, Сафиулла абзый ---. Ул төрмә дигәнең дә бу тормыштан начар түгелдер, шәт. Эт тормышы бу!* Г.Иделле. **Эт тубыгыннан** Бик күп, һәркайда тулып, өелеп яткан, кадерсезгә калган әйбер һәм кешеләр турында. *Хәзер базарда карбыз эт тубыгыннан. Һәркайда тулып ята, буа бу.* Г.Минский. **Эт туе** Тәртипсез кешеләр төркеме. **Эт туе ясау** 1) Бозыклыклар эшләү, әхлакый таркалган кешеләр белән аралашу; 2) Сугышу, кыйнашу; тавыш-гауга, шау-шу кубару. *Барыгыз, чыгыгыз әле моннан, эт туе ясамагыз.* Г.Камал. **Эт тырнагы** Яманның яманы, сатлыкҗан кеше. **Эт урынына** Каты итеп, бик нык (тиргәү, кыйнау тур.). *Озак йөрисең дип, Гыйрфан абзый эт урынына ярды.* Г.Ибраһимов. --- *ачуымны китерсәң, яраткан малаем диеп тормам, чалбардан каешны чишеп алырмын да эт урынына тотып ярырмын, ди...* Г.Мөхәммәтшин. **Эт урынына да күрмәү** Берәүнең кешелек дәрәҗәсен, абруен танымау, санга сукмау. *Хәдичә күңелдән ярлы кешене эт урынына да күрми.* З.Һади. **Эт урынына йөртү** Кешене кол итү, көченнән файдалану, кадерсез итү. *Әле дә унбиш ел эт урынына йөрттең!.. Монда калып, сезнең этләрегездән талатыр хәлем юк.* Г.Ибраһимов. **Эт халык** *к.* **этҗан** (*2 мәгъ.*). – *Хатын белән расчёт. Бик эт халык булып чыкты ул, малай, уҗымга йөрде ---, – диде Мөби.* М.Мәһдиев. **Эт хәтере (өчен) түгел, иясе хәтере (өчен)** Әһәмиятсез кешеләргә карата күрсәтелгән илтифатның чын сәбәбе хуҗага, түрәгә хөрмәт күрсәтүгә, ялагайлануга кайтып калу турында. **Эт чаба дип, бет чаба** Берәүнең хәленнән килмәсә дә, хәлле, булдыклы, абруйлы кешеләрдән күреп, шуларга иярергә маташуы, булдыра алмаслык эшләргә керешүе турында. --- *хәзер --- эт чаба дип бет чаба, дигәндәй, һәркем үзенә мөмкин кадәр күбрәк байлык туплап калырга тырыша.* Р.Миңнуллин. **Эт чыкмас (чыкмаслык, чыккысыз)** *к.* **эт йөргесез**. *Карт исәнлек-саулык сорашмастан: – Алла бәндәсе, эт чыкмас мондый көндә нишләп йөрисең?! – диде.* Х.Сафина. **Эт эзләп таба алмаслык** Ерак урнашкан, яшерелгән, кеше табарлык булмаган. *Аннары, үзалдына сөйләшкән кебек, болай диде: – Һичбер эт эзләп таба алмаслык объектны эзләп таптты... Кара син аны, молодец!* С.Баттал. **Эт эткә, эт койрыкка** Эшне беркем дә башкарырга теләмичә, берсе икенчесенә, икенчесе өченчесенә кушу. *Син аңа әйтеп кенә калма, эт эткә, эт койрыкка булмасын, приказын язып куй.* М.Хәбибуллин. *Мөнә кайчаннан бирле йөрим, эшемне карамыйлар, хакымны ала алмыйм. Утыралар шунда эт эткә, эт койрыкка.* Ю.Әминов. **Эт этлеген итә** Начар, әшәке кеше һаман әшәкелек эшләвен дәвам итә. *Хәер, киңәшләр белән генә әллә ни майтара алмыйсың, юкка гына, эт этлеген итә, димиләрдер.* Татарстан яшьләре. **Эт этлегенә бара** *к.* **эт этлеген итә**. **Эт эченнән өйрә эчкән** Саран кеше. **Эт яламас** 1) Ямьсез, җирәнгеч, җан биздергеч нәрсә, зат турында әйтелә; 2) Начар, тиешле дәрәҗәдә түгел. *Урыс исә көннәр буе былагайланып, эшләгән булып йөри, башкарган эше – эт яламаслык.* А.Гыйләҗев; 3) Әшәке, тупас, сүгенүле сүзләр турында. *Пыр тузып талашалар тегеләр, --- теш араларыннан чыккан сүзләре эт яламаслык иде.* А.Гыйләҗев. **Эт ялар каны юк** Үтә ябык, төссез кеше турында. **Эт ялкавы** Бик ялкау, булдыксыз, эшлексез. *[Хәдичә:] Фәррах карт җандай кызын шул Мөҗаһиткә бирергә ризалашканмы шәт? Эт ялкавына?!* А.Гыйләҗев

**ЭТАВЫЗ** *и. кимс.* Әшәке телле, сүгенеп сөйләшүче кеше. *Егетен дә бик мактап бетермиләр, кайнана – бик этавыз нәрсә, ди, Гөлбануга бер дә якты көн бирмәс, диләр ---.* Г.Ибраһимов

**ЭТАЖ** *и. фр.* 1) Бинаның бер биеклектә урнашкан бүлмәләр рәтен тәшкил иткән өлеше; кат. *Өенә кайтып, үз этажына менгәндә, икенче катта Булавиннар ишеге төбенә тукталып, ул звонокка үрелде.* А.Гыйләҗев. *Арадан телгә җор бер иптәш әйтте: – Тәрәзәне ватып маташма, бу – беренче этаж, – диде.* М.Мәһдиев

2) *күч.* Бер дәрәҗәдә урнашкан предметлар рәте; катлам. *Гилокомиум ыругы мүкләре фунария белән чагыштырганда бик зур булып күренә. Ул берничә «этаж»дан тора, аның төп сабактан үсеп чыккан сабакчыклары шулай урнашкан.* Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы

**ЭТАЖЕ́РКА** *и. фр.* 1) Таяк яки такта тирәкләргә аслы-өсле шүрлекләр куеп ясалган җиһаз. *Ак чыбыктан үрелгән этажеркада китаплар тезелгән.* Г.Әпсәләмов. *Берни булмаган кебек, ул ике тәрәзә арасындагы этажерка янына килде, урындыкка утырды да этажеркадагы таныш китапларны караштыра башлады.* Н.Фәттах

2) Сәнәгатьтә технология җиһазларын урнаштыру өчен, тимердән яки корычтан ясалган каркас, корылма

**ЭТАЛОН** *и. фр.* **1.** 1) Билгеләнгән үлчәү берәмлеге үрнәге. *Метр – халыкара эталонга (үрнәккә) сызылган ике сызыкча арасындагы ераклык ул.* Физика

2) Башка үлчәү җайланмаларын тикшереп тору өчен кулланыла торган төгәл үлчәү үрнәге яки приборы. *Паузалар, гүя миллисекундлар белән үлчәнеп, эталон дәрәҗәсенә китерелгән.* Р.Заһидуллина

3) *күч. кит.* Берәр нәрсәнең иң әйбәт мисалы, чагыштыру, иярү өчен үрнәк, өлге. *Татар прозасының эталоны, миңа калса, Ибраһимов, Еники, Әмир, Сарьян әсәрләре.* Р.Миңнуллин. *Бер уйлаганда, шуннан да яхшы кешенең булуы мөмкин түгел – идеаль ир эталоны инде, тот та музейга куй!* Ж.Рәхимов

**2.** *с. мәгъ.* Үрнәк, төгәл стандарт булып торган; үлчәү үрнәге функциясен үти торган. *Контроль-үлчәү приборларының техник торышын карап яки эталон приборлар белән тикшереп беләләр.* Урып җыю машиналары

**ЭТАН** *и. гр. хим.* Нефть һәм табигый газдан алына торган янучан, иссез, төссез газ рәвешендәге органик кушылма; $C_2H_6$. *Житди кыяфәтле, җыйнак, пөхтә аппаратчылар --- промыселлардан килгән газны состав матдәләренә аералар: этан, пропан, бутан --- һәм башкалар...* М.Зарипов

**ЭТАНОЛ** *и. лат. хим.* Этил спирты; исерткеч эчемлекләрнең тәэсир итә торган өлеше. *Этанолның иң зур концентрациясе баш миендә, бавырда була.* Сәламәтлек нигезләре. *Аннан соң машина тәрәзәсен юу өчен кулланыла торган күп кенә сыеклыклар составында да этанол бар.* Татарстан яшьләре

**ЭТАП** *и. фр.* 1) Нәрсәнең булса да үсешендә аерым стадия, момент, чор. *Табигатьнең сыгылмалылыгы, үз-үзен*

*көйләү сәләте никадәр соклангыч булмасын, цивилизациянең хәзерге этабында табигать үз көче белән генә пычрактан арына --- алмый инде.* Р.Мостафин. *Очышның иң җаваплы этабы уңышлы үтте.* Р.Ибраһимов

2) *хәрби* Бер җирдән икенче җиргә күчкәндә хәрби хезмәткәрләрне фатир, азык-төлек, медикаментлар, фураж белән тәэмин итә торган пункт

3) Арестантларны мәҗбүри рәвештә сөрген, төрмә һ.б.ш. җәза урынына алып бару, илтү. *Буйсынмаган галимнәрне анда Этап белән ерак куалар.* Г.Кутуй. *Язмыш аны Иркутски ягындагы Александровский централы дигән төрмәгә этап белән китергән.* З.Зәйнуллин // Шул урынга кадәр үтелгән юл. *Этаплардагы юл газаплары хакында том-том китаплар, меңнәрчә кайгылы хатирәләр инде язылган.* А.Гыйләҗев. *Этапларда этләр талаганын Карап барды синең бабакләр.* Р.Әхмәтҗанов // Арестант төркемнәренең шул юлда кунып чыга торган пунктлары. *Поезддан төшерделәр дә, яңадан бик җентекләп барлап, этап дворына алып киттеләр.* М.Хәсәнов

4) Сак астында озатыла торган арестантлар төркеме яки партиясе. *Этаплар китә тора, этаплар килә тора. Көндезләрен бик сирәк килеп төшә торган этап кабул итү вакыйгасын тамаша итәргә байтак тоткын җыйнала.* А.Гыйләҗев. *Декабристлар килеп туктадылар Этап белән төрмә алдына.* Г.Латыйп

5) *спорт* Спорт ярышларында (нигездә эстафеталы ярышларда) билгеле бер дистанция арасы. --- *Габделнур да сынатмады: шәхси беренчелектә икенче урынны алды, эстафетада да өч этапта иң ахырдан килүче каравыл ротасын бу хурлыктан коткарды – унбер команда арасында бишенче урынга менгезде.* Р.Кәрами. *Ярышның соңгы этабында Булат, үзе суга сикереп төшеп, Кәримовка көч бирерлек булып утырды.* Р.Шәмсетдинова

**ЭТАПЧЫ** *и.* Этап белән баручы арестант. *«Этапныкылар, тышка чыгыгыз!» Тагын ыгы-зыгы. Ишек төбендә конвой башлыгы этапчыларның «гамәл дәфтәрен» укый.* И.Салахов

**ЭТӘРГЕЧ** *и.* **1.** Берәр күренешне китереп чыгара, шуңа булышлык итә торган алшарт; берәр эшкә кызыксыну, теләк уята торган сәбәп; стимул. *Һәм әнә шул хәбәр, инде булмый, дип ташлаган хикәямә яңадан тотынырга этәргеч булды.* В.Нуруллин. *Телисеңметеләмисеңме, бу азгын кеше белән Гөлфинурның якынаюына этәргеч ясаучы кеше дә ул – Рәфис булып чыга лабаса.* А.Вергазов

**2.** *с. мәгъ.* Нәрсәне дә булса башкарырга этәрә торган. *Патриотлык – кемдер уйлап чыгарган нәрсә түгел: ул мәнә безнең кебекләрнең тирән күңел түрендә утыра, безнең өчен иң беренчел этәргеч көч булып тора...* З.Мифтахов

**ЭТӘРЕШ** *и.* 1) Этәрү хәрәкәте, шуның көче, колачы. *Көчле этәреш ясау*

2) *к.* **этәргеч**. *Комсомол эшендә чыныгып, зур практик эш тәҗрибәсе алып, Мәскәүгә эшкә килү минем иҗатыма зур этәреш бирде, миндә иҗат активлыгы нык күтәрелде.* М.Җәлил. *Күләме кыска гына булса да, бу язма директор бүлмәсендә зур сөйләшү кузгатырга этәреш бирә.* С.Сабиров

3) *к.* **этеш-төртеш**. *Кычкырыш, тавыш, тегендә-монда этәреш, тапташ, кысылыш, белмәм, тагы ниләр булып, дөньяның астын өскә китергәндәй кабалану белән берәр минут вакыт үткәннән соң, өч-дүрт йөз кешеле җәмәгать ишектән, тәрәзәдән качып чыгып бетәргә өлгерә алды.* Г.Ибраһимов

**ЭТӘРЕШҮ** *ф. урт. юн. к.* **этәрү**. *Кычкырышалар. Бәрелешәләр. Берберен этәрешәләр. Әйтерсең дөньяның асты өскә килә.* Г.Ибраһимов

**Этәрешә башлау** Этәрешергә тотыну

**Этәрешеп йөрү** Озак вакыт дәвамында этәрешү. *Мәнә шул ике кеше сөлге белән бер-берсенең биленнән кысып тоттылар да --- мәйданның бер читеннән икенче читенә этәрешеп йөри башладылар.* М.Яһудин

**ЭТӘРҮ** *ф.* 1) Кискен хәрәкәт белән этү, читкә кагу. *Фәхри, ишекне ачып, бусагадан атлыйм гына дигәндә, Мәрьям --- аны арткарак этәрә дә, нәкъ йөрәгенә таба төзәп, беррәттән өч мәртәбә ата.* Г.Ибраһимов. --- *карт пошн --- ризасызлык белдереп, башын чайкап куйды да, күкрәге белән этәрә-этәрә, ана пошины урман эченә алып кереп китте.* В.Нуруллин

2) Нәрсәне дә булса кул белән этеп берәр якка күчерү, күчереп кую. *Шул сый-хөрмәтне алдыңа этәрә-этәрә, авыз ачарга ирек бирмичә, чын күңелдән кыстарга тотыналар ---.* Г.Бәширов. *Ул, --- башын күтәреп, бер кулы белән яфракларны читкә этәрә дә тирә-ягына карана.* Г.Әпсәләмов // Янякка этү, аралау. *Аның зур гәүдәле кара аты, киң күкрәге белән башка атларны этәреп, чанага якынлашты.* Н.Яһудин

3) Нинди дә булса көч ярдәмендә берәр нәрсәне кысып чыгару, кудыру. *Һава басымы белән суны этәрү*

4) *спорт* Махсус авыр спорт әсбабын көчле кискен хәрәкәт белән этеп җибәрү. *Ядрә этәрү ярышы*

5) *күч.* Нәрсәнең дә булса сәбәпчесе булу; нәрсә дә булса эшләргә теләк тудыру, мәҗбүр итү. *Үзенең шундый чакта каушап, югалып калуыннан туган гарьлек хисе аны әллә ни уйларга этәрә иде.* М.Галиев. *Шушы башбирмәс, үзсүзле, тискәре Гөлназ аны усал булырга этәрә.* И.Нәбиуллина

6) *күч.* Кемне дә булса кыерсыту; читкә кагу, читләштерү. *Таһир белән Зөһрә арасындагы көчле мәхәббәтне күреп, хан Таһирны читкә этәрә.* М.Җәлил. *Бер анадан булсалар да, энекәшләре Җүчине тәхеттән читкә этәрәләр.* А.Хәсәнов

**Этәрә башлау** Этәрергә тотыну. *Уң яктан кемнәрдер --- этәрә башлыйлар, дулкын үзенең ташкыны белән Герасимовны да элеп алып китә дә зур коймага китереп тери.* Г.Ибраһимов. *Халык җыела тора, әйбәт урын таптык, дип сөенергә өлгермәделәр, кысрыклап читкә этәрә башладылар.* Ф.Сафин

**Этәрә төшү** Бераз, беркадәр этәрү. *Мәрьямбикә иренең алдына табактагы катыкны этәрә төште.* Г.Ибраһимов. *Урмановны кочаклаганда, аны үзеннән бераз этәрә төшеп, җибәрмичә торды.* Г.Әпсәләмов

**Этәреп җибәрү** Кинәт этәрү. --- *ул тураеп басты да маңгаеннан тир тамчыларын сөртергә дип үрелгән операция сестрасының кулын этәреп җибәрде ---.* М.Маликова. *Гибралтар, төрткәли-төрткәли, Миңнисаны залга таба этәреп җибәрә.* Л.Лерон

**Этәреп кую** Этәреп, шул урында, шул хәлдә калдыру. *Кулымны сузып, янымдагы тула төргәген стена буена ук этәреп куйдым.* Г.Бәширов. *Кыз исә түр як бүлмәгә ташланды һәм ишек эшергечен этәреп куйды.* М.Хәбибуллин

**Этәреп тору** Һәрдаим, әледән-әле этәрү; хәзерге вакытта этәрү. *Төркиядә --- якын арада ук инде пенсиягә чыгу яшен ирләргә илле биштән хәл итү карала. Илдә гомер озынлыгы арту да шуңа этәреп тора.* Т.Әйди. *Әйе, батырлык онытылмый! Яшь эзтабарларның күңелләрен ул һәрвакыт үзенә тартып, яңа эзләнүләргә этәреп тора.* Ш.Мостафин

**ЭТӘ́-ТӨРТӘ** *рәв. к.* **этеп-төртеп**. *Гөлчәчәк, этә-төртә, мине Барый янына чыгарга кыстый.* З.Хөснияр. *Тик капка төбен сырып алган бала-чага, берсен берсе этә-төртә, һәркайсы алгарак чыгарга тырышып: – Яшь килен апай безгә дә күчтәнәч бирер әле, – дип, чыр-чу килә башлады.* Г.Галиева

**ЭТБАГАР** *и.* Эт караучы, эт тәрбияләүче. *Менә беркөнне приказчик этбагар Ермилны чакыра: «Ермил, пошта алып кайт әле», – ди.* И.Тургенев

**Э́Т БАЛЫГЫ** *и. зоол.* Эт балыклары семьялыгыннан авыз тирәсендә мыекчасы булган, озынча суалчан сыман гәүдәле, бик вак тәңкәле яки тәңкәсез бик елгыр төче су балыгы; *русчасы*: **вьюн**. *Бергә күрше булып үскәннәр. Шаралы, чебенле уйнап, Эстәрле суында кәрҗин белән ташбаш, маймыч, эт балыклары тотканнар.* З.Зәйнуллин. *– Әсфәндияр, монау эт балыгын йолкып ат әле, – дигәнен ишетте.* Ә.Гаффар

**ЭТБАЛЫК** *и. зоол.* 1) Дүрттешлеләр семьялыгыннан зур башлы, пластина рәвешендәге нык кына дүрт тешле балык; *русчасы:* **рыба-собака**. *Этбалык --- дип тә аталып йөртүче бу балыкта цианидтан да көчлерәк тетродотоксин дигән агу бар, ди.* Ватаным Татарстан

2) *диал. к.* **эт балыгы**

**ЭТБАШ** *и. кимс. к.* **этҗан**. *– Менә ул, этбаш! – дип, солдатның кычкырганы ишетелде. – Яшеренеп ята, картлач.* А.Расих

**Э́Т БАШЛЫ МАЙМЫЛ** *и. зоол. иск.* Мартышкасыманнар семьялыгыннан башы этнекенә охшаш маймыл; *русчасы*: **собакоголовая обезьяна, павиан**. *Карадым: йөз-мең фил, арыслан вә юлбарыс, бүре, шакал, төлке, аю, кабан дуңгызы, эт башлы маймыллар – һәммәсе сарай тирәсенә җыелдылар.* Борынгы татар прозасы

**Э́Т БОРЧАГЫ** *и. бот.* Мальвачалар семьялыгыннан төрле төстәге эре чәчәкле, калын сабаклы, ашамлык һәм терлек азыгы итеп кулланыла торган декоратив һәм дару үләне; мальва

**Э́Т БОРЫНЫ** *и. бот. диал.* Гөлҗимеш. *Гөләпне (шиповник) «гөлҗимеш», «эт борыны», «аю табаны», «аю камыры» диләр.* Ватаным Татарстан

**Э́Т ГӨРЕҖДӘСЕ** *и. бот.* Ал гөмбәчәләр семьялыгыннан каенлыкларда яки нарат катыш каенлыкларда үсә торган ашарга яраклы гөмбә; *русчасы:* **собачий груздь**. *Быел эт гөреҗдәсе күп*

**ЭТЕ́-БЕТЕ** *җый. и. гади с.* Теләсә кем, ыбыр-чыбыр, юк-бар кешеләр. *--- әни-әтисенә, туган-тумачаларына, --- энесе Самат кебек әбер-чебергә, этенә-бетенә бүләкләр, күчтәнәчләр җыйды Зөлфия.* Т.Галиуллин. *Тәнәфес саен мәктәпнең эте-бете шул Нәбине сырып ала.* Х.Ибраһим

**ЭТЕЛӘ́-КЫСЫЛА** *рәв. к.* **этелеп-төртелеп**. *Этелә-кысыла алга үрелдем.* М.Җәлил. *Ял көне – якшәмбе булса да, халык күп иде, көч-хәл белән этелә-кысыла керде.* Р.Кәрами

**ЭТЕЛӘ-ТӨРТЕЛӘ** *рәв. к.* **этелеп-төртелеп**. *Студентлар актлар залына агыла башладылар. Бер нәрсә аңламасам да, этелә-төртелә, мин дә шунда үттем.* Р.Вәлиев. *Чиратларда, этелә-төртелә, сәгатьләр буе торган чаклар да еш була.* Р.Миңнуллин

**ЭТЕЛЕ́П-КЫСЫЛЫП** *рәв. к.* **этелеп-төртелеп**. *Этелеп-кысылып, билетка чират торган чакларын, унөченче вагонның унөченче урынына билет алганын хәтерендә яңартты.* Р.Мулланурова

**ЭТЕЛЕ́П-ТӨРТЕЛЕП** *рәв.* 1) Кеше күп булган урында, аларга бәрелеп, орынып, кысанда кешеләр арасыннан ерып үтәргә тырышып. *Сигез сәгать буе юлда килеп, шәһәр эчендәге автобусларда этелеп-төртелеп йөреп, минем өс-башым ярыйсы ук таушалган иде.* Г.Афзал. *Алар автор ихтыяры белән этелеп-төртелеп йөрүче курчаклар түгел.* Ф.Галимуллин

2) *күч.* Бик авырлык, зур киенлык белән. *Гомере буе кыйналып, этелеп-төртелеп яшәде.* Р.Мостафин

**ЭТЕЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **этү**. *Коридорда исә җилкәсеннән эләктереп, этелеп барган Гата, гармунын бер дә кызганмыйча үкертеп, җырлый иде ---.* М.Мәһдиев

2) Бер якка, бер кырыйга тайпылу, тартылу. *Хәлим, кулларын кесәләренә тыккан килеш, Каюмны читләтеп узмакчы булган иде, тегесе гәүдәсен катырып, Хәлимгә таба этелде.* Г.Гобәй. *Кискен җил аны туктатып-туктатып калдыра. Аннан, күкрәге белән этелеп, тагын атлап китә.* Ә.Гаффар

**Этелә башлау** Этелергә тотыну. *Ионнар арасындагы ераклык аз гына кимесә дә, алар бер-берсеннән этелә башлыйлар.* Физика

**Э́Т ЕЛЫ** *и.* Һәр елы аерым бер хайван исеме белән аталган унике еллык циклда 11 нче ел. *Истәлекче, яз. Эт елында мин, Бөек Болгар ханы Кубрат, үземнең җәйләүләремне илханнарга бүлеп бирергә булдым.* М.Хәбибуллин. *1156 сәнә эт елы, һава йөзендә бер койрыклы йолдыз пәйда булды, койрыгы кояш инеше тарафында иде ---.* Г.Гобәйдуллин

**ЭТЕМ** *и. физ.* Берәр өсйөзгә юнәлтелгән механик тәэсир көче, басым

**ЭТЕ́П-ТӨРТЕП** *рәв.* 1) Тирәяктагыларны як-якка кысрыклап, этәреп, берәр җиргә керү, урнашу өчен үзеңә юл ярып. *Вагон шыгрым тулган булуга карамастан, халыкны һаман этеп-төртеп кертеп торалар.* Г.Әпсәләмов. *Кызлар, егетләр, шаулашып, бер-берсен этеп-төртеп, арткы ишектән кузовка төялделәр.* Н.Фәттах

2) *күч.* Ирексезләп, көчләп, кыстап, ашыктырып. *Халидә тораташ иде. Нурсөя аны этеп-төртеп кенә кузгатты.* Н.Гыйматдинова. *Ярты көнне ничек кирәк алай этеп-төртеп уздыргач, Фаягөл, «хәерле сәгатьтә» дия-дия, урамга чыкты.* А.Әхмәтгалиева

**ЭТЕШӘ́-ТӨРТЕШӘ** *рәв. сөйл.* Бер-береңне як-якка кысрыклап, этәреп, берәр җиргә керү, урнашу өчен, һәркем үзенә юл ярып. *Кешеләр сүзсез генә, кысылышып, түземлек белән генә, этешә-төртешә [автобуска] кереп тулдылар.* А.Гыйләҗев. *--- чиләкләр күтәргән чабаталы халык, бер баласын күтәргән, икенчесен итәгенә ябыштырган хатын-кыз этешә-төртешә пароходка ябырылды.* Г.Афзал

**ЭТЕ́Ш-ТӨРТЕШ** *и.* Бер-береңне этү, төртү күренеше. *Чират булыр, этеш-төртеш булыр, юньләп кереп, юньләп ял итеп булмас, дим.* Г.Зәйнашева. *Әхмәтсафалар килеп җиткәндә, анда ерып чыккысыз халык иде. Һәркем алга үтергә маташа, тавышсыз гына этеш-төртеш, урын өчен көрәш бара.* Ф.Сафин

**ЭТЕШҮ** *ф. урт. юн. к.* **этү**. *Кызганып, атка булышкандай этешеп җибәрәм.* Ш.Галиев. *Гөлбикә мунчага кереп киткәч, яшүсмерләр --- мунчаның тәрәзәсе янына җыелып, бер-берсенең башларын этешеп, кечкенә тәрәзә янында юеш җирдә яталар иде.* М.Мәһдиев. *Авыр йөк төялгән арбаларны сөйри алмыйча чыгымчылаган малларга кешеләр этешеп, булышып барды.* Р.Сәгъди

**Этешә башлау** Этешергә тотыну. *--- кызый интеккән кешегә булышырга кирәк дип тапты һәм, базар сумкасын каен төбенә сөяп, кулларын бушаткач, яшел вагонның артыннан этешә башлады.* К.Кәримов

**Этешеп алу** Кыска вакыт эчендә, аз гына этешү

**ЭТҖАН** *и. кимс.*1) Гаять чыдам, түзем, бернигә бирешми торган кеше

2) Әрсез, гарьсез, оятсыз кеше. *Мирфатыйх та кызган иде. Ничек инде, ул – үз бакчасында, хуҗа кеше, кемдер этҗан монда кереп, аны кыдырып, боерып йөрсен әле!* А.Гыйләҗев. *Төш, этҗан! Гайбәтең белән дөнья сасытма. Кияү дип тормам, измәңне изәрмен!* Н.Гыйматдинова

3) Мәкерле, астыртын, явыз кеше. *Дуслар гына түгел, бүгенге яшәвемнең токталары сез, этҗаннар.* Г.Рәхим. *– Әгәр дә мәгәр ишетәм икән, – диде Зөфәр, һәр сүзенә басым ясап, – әҗәлең кавызда булыр, этҗан.* М.Хәбибуллин. *Килсен, килмәсә, битлеген ертып, этҗан икәнлеген фаш итми калмабыз.* Э.Касыймов

**Э́Т ҖИЛӘГЕ** *и. бот.* Паслёнчалар семьялыгыннан эре чәчәкле, ялтырап тора торган кара җиләкле, күпьеллык агулы үләнчел үсемлек; *русчасы*: **белладонна**. *Паслёнчалар семьялыгына агулы үсемлекләрдән тилебәрән, дурман, эт җиләге керә.* Биология. *Биостимуляторлардан эт җиләге, женьшень, радиола, элеутерококктан әзерләнгән төнәтмәләр кулланырга киңәш ителә.* Сәламәт булыйк!

**Э́ТИК** *с.* Этикага караган; этика таләпләренә, кагыйдәләренә туры килә торган. *Ирешелгән уңышларны күпләр иңенә таратып, кылган хаталарны бер шәхескә генә аударып калдыру нинди этик кануннарга туры килә икән?* М.Галиев. *Әдәбияттагы этик, эстетик, әхлакый проблемаларны күтәргән, үткен полемикага корылган ул язмаларны мин эссе жанрына кертер идем.* Р.Миңнуллин

**Э́ТИКА** *и. гр.* 1) Иҗтимагый аңның бер формасы буларак әхлак, үз-үзеңне тоту кагыйдәләре турында фәлсәфи тәгълимат. *Кайберләре санаторийда егерме дүрт көн ял итү, дәвалану дәверендә парларны ике көннең берендә алмашалар. Әхлак, этика, әдәп кануннары юк ул кешеләрдә.* Г.Тавлин. *Сыйныфтан тыш уку дәресе сыйныф җитәкчесе, әдәбият укытучысы, этика һәм психология укытучысы тарафыннан үткәрелә.* Ә.Хуҗиәхмәтов

2) Аерым җәмгыять, иҗтимагый катлау яки нинди дә булса профессия әгъзалары арасында кабул ителгән әхлак нормалары, мораль. *Сез, Баязит Алмасович, – тәҗрибәле хирург, эрудицияле врач, шулай да этика дигән нәрсә җитеп бетми үзегезгә.* С.Сөләйманова. *Менә хәзер Закировка --- гап-гади информация ясарга кирәк. Дөрес, ул моны иртәгә заводның культура сарае директорыннан сорашып та белә ала иде. Тик журналист этикасы, кешелек намусы моны кабул итмәде.* Р.Кәрами

**ЭТИКЕТ** *и. фр.* Нинди дә булса җәмгыять, иҗтимагый катлау яки профессия әгъзалары арасында кабул ителгән әхлак, үз-үзеңне тоту, әдәп кагыйдәләре. *Рейганның берәр җиргә – визитмы анда, кунак каршылаумы – хатыны белән йөрүе һич гаҗәп түгел. Этикет, диярләр кайберәүләр.* Р.Зәйдулла. *Этикет кагыйдәләре буенча, бүлмәгә кергән кешенең исемен беренче итеп әйтергә кирәк.* Матур буласың килсә

**ЭТИКЕ́ТКА** *и. рус* Товар, экспонат ишеләрнең исемнәре, бәясе һ.б.ш. күрсәтелгән ярлык. *Шешәгә без яшьлектә күргәләгән этикетка ябыштырылган: анда Арарат тавы һәм аның тирәсендәге табигать манзарасы иде.* М.Мәһдиев. *Менә бу тун әле бер дә киелмәгән. Хәтта яка астында этикеткасы да бар.* Ф.Яруллин

**ЭТИКЕТКАЛА́У** *ф.* Этикетка ябыштыру, этикетка беркетү. --- *икенчесе үлчәгәнне --- банкаларга бушата тора, аннары аларны бөкеләү, этикеткалау һәм тиешенчә төреп, ящикларга урнаштыру өчен, өстәл буйлап бүтәннәргә таба эшерә тора...* Э.Касыймов

**Этикеткалап бетерү** Барысын да этикеткалау

**Этикеткалый башлау** Этикеткаларга керешү

**ЭТИКЕ́ТКАЛЫ** *с.* Этикетка беркетелгән, тагылган, этикеткасы булган. *Эдик мине өстәл янындагы йомшак кәнәфигә утыртты да тумбочкасыннан матур гына этикеткалы бер шешә чыгарды.* М.Юныс. *Ул өстәлдәге гарәпчә язылган этикеткалы елтыравык сигарет кабына карады ---.* Ш.Маннапов

**ЭТИЛ** *и. гр.* Углерод белән водород атомнарыннан торган, күп кенә органик кушылмалар составына кергән бервалентлы органик радикал. *Икенче әһәмиятле сәбәп: әчешү вакытында, организм өчен зарарлы матдәләр – этил һәм бутил спиртлары, сөт һәм май кислоталары, ацетон һәм башка матдәләр барлыкка килүдә.* Кызыклы физиология

**ЭТИЛЕН** *и. гр. хим.* Углерод белән водородтан торган төссез, тиз янучан газ (полиэтилен, стирол, этил спиртын алуда кулланыла). *Полиэтилен өчен этилен да җитештерәбез.* Р.Миңнуллин. *Бүгенге көндә дәүләт өчен, Дмитриевка юлына караганда, этилен цехлары арасындагы юллар мөһимрәк.* Ф.Абдуллин

**ЭТИМО́ЛОГ** *и. гр.* Сүзнең килеп чыгышын, үсешен тикшерүче белгеч, этимология галиме. *Бу сүзнең килеп чыгышын ачыклау турында бер Гордеев кына шөгыльләнми, байтак этимологлар бу турыда баш вата.* Р.Батулла. *Этимологлар, чуваш һәм марилардагы «чүк» сүзен татар теленнән, татар мәҗүсилегеннән алынган, диләр.* Н.Максимов

**ЭТИМОЛОГИЗА́ЦИЯ** *и. рус лингв.* Нинди дә булса сүзнең этимологиясен ачыклау. *Р.Әхмәтьянов, рус телендәге «белка» сүзе башта вак акчаны белдергән һәм татарча «акча» сүзенең калькасы булып тора, дип яза, ягъни аның этимологизациясендә тиен җәнлеге бөтенләй катнашмый, ди.* А.Тимергалин

**ЭТИМОЛОГИЗА́ЦИЯЛӘҮ** *ф.* Этимологиясен, килеп чыгышын билгеләү, ачыклау. *Бу таләп бигрәк тә идентификация мәсьәләсендә, ягъни этимологизацияләргә алынган сүзләрнең барысы да чыннан да шул ук сүзме, дигән сорауга җавап биргәндә чагыла.* Р.Әхмәтьянов

**ЭТИМОЛО́ГИК** *с.* Этимологиягә мөнәсәбәтле, этимологиягә караган. *«Чабата» сүзен, этимологик яктан, «чыпта» сүзе белән янәшә карарга да мөмкин ---.* А.Тимергалин. *Гомумән, этимологик фаразлар, «кырык иләк» аша үткәрелгәч кенә, тулысынча ышандырырлык булалар, һәм шул чагында гына алар тарих өчен табыш вә материал булалар.* Р.Әхмәтьянов

**ЭТИМОЛО́ГИЯ** *и. гр. лингв.* 1) Сүзләрнең килеп чыгу тарихын, беренчел структураларын һәм семантик бәйләнешләрен өйрәнә торган тел белеме тармагы. *Тел белемендә сүзләрнең килеп чыгышын өйрәнә торган этимология дигән фән дә бар.* Ә.Еники

2) Сүзләрнең килеп чыгышын өйрәнә, билгели торган алымнар җыелмасы

3) Сүз яки морфеманың килеп чыгышы, тарихы. *Эти кайвакытта сүзнең этимологиясе белән дә шөгыльләнә иде.* М.Мәһдиев. *Р.Әхмәтьянов «чыңгыз» исеменең этимологиясен «тәңре» атамасына бәйле карый.* Г.Шәйхиева

**ЭТИМОН** *и. гр. лингв.* Хәзерге телдәге билгеле сүзнең иң борынгы, беренчел формасы һәм мәгънәсе. *Мамонт*

*сүзен XVIII гасыр галимнәре «Себер татарлары теленнән» дип язганнар. Ләкин сүзнең төгәл генә этимоны бүгенгәчә табылганы юк ---.* Р.Әхмәтьянов

**ЭТ ИМЧӘГЕ** *и.* Култык астына чыга торган чуан, эренле шеш. *--- К.Насыйри үзенең Казан татарларының йолалары һәм ышанулары турындагы хезмәтендә «эт имчәге» имләгәндә әйтелә торган сүзләрне китерә.* Р.Ягъфәров

**ЭТИОЛОГИЯ** *и. гр.* 1) Медицинаның теге яки бу авыруның килеп чыгу сәбәпләрен һәм шартларын өйрәнә торган тармагы. *Авыруның табигатен тирәнрәк аныклау теләге аны этиология, патогенез, эпидемиология һәм башка тармакларга да алып керә.* Т.Әйди. *Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының этиология --- бүлеге мөдире Дарья Даниленко белдерүенчә, Россиядә быелгы сезонда грипп эпидемиясе былтыргыга караганда бераз түбәнрәк булыр дип көтелә.* Мәйдан

2) *мед.* Теге яки бу авыруның сәбәпләре. *– Авыруның сәбәбен белмичә дәвалау җиңел түгел, – дип куйды Сергей Матвеевич, төшенке тавыш белән. – Этиологиясе ачыкланмаган очракларда да авыруны дәвасыз калдырмыйсыздыр бит? – диде --- Вилен.* М.Маликова

**ЭТ КАКЫСЫ** *и. бот.* Әвернәчәчәкләр семьялыгыннан түбәндәге яфраклары лирасыман, югарыдагылары тоташ челтәрле, хуш исле сары чәчәкле, орлыгы агулы баллы чүп үләне; кыр кәбестәсе; *русчасы*: **сурепка**. *Эт какысы кыргый тормага охшаган.* Биология. *Эт какысының җимеше – ике капкачлы озынча кузакча. Болыннарда, аланнарда, юл буйларында һәм басуларда эт какысы апрель азагында һәм май аенда чәчәк ата.* Ботаника

**ЭТ-КОШ** *җый. и.* Һәртөрле этләр, кошлар һ.б. хайваннар. *Хатын, әйберләрен яшерә төшеп, утынлыкка килде, эт-коштан сакланырга бер нечкә имән таяк алды да азбарга, аннан ындырга чыкты.* Г.Ибраһимов. *Бигрәк тә әтием минем өчен курка, урамда эт-кош күбәйде, ди...* Ә.Еники

**ЭТКҮЗ** *и. кимс.* Тиешне дә, тиешсезне дә күреп-сизеп торучы кеше

**ЭТЛӘЙ** *и. диал.* Эт балыгы. *Хәзер Зичәдә ташбаш, этләй, сирәк-мирәк кенә чабаклар күренгәли.* Р.Батулла. *Менә мин үзем чуртан белән этләйне таныйм. Болар ни чуртанга, ни этләйгә охшамаган балыклар иде.* И.Кашфразыев

**ЭТЛӘНҮ** *ф. сөйл.* 1) Азаплану, интегү, җәфалану, кыенлык күрү. *Үзебез әлегә хатынның әниләрендә, иске генә бер йортта яшәп этләнәбез.* А.Хәсәнов. *– Менә, Рәфхәт Шәкүрович, шушы катыргыны алу өчен, миңа күпме этләнергә туры килде, – дип, миңа таба документын сузды.* Р.Зарипов

2) Әрсезләнү, үҗәтләнү. *Әлтафи тәки этләнде, әмма номерны әйтеп торучы Нинадан үзе теләгәнне эшләтте: «Әсәрне сәхнәләштерүче Әлтафи Хәлимов» дигәнне әйттерде.* М.Мәһдиев

**Этләнә бару** Торган саен ныграк этләнү. *Теге үгез дә көннән-көн этләнә барды.* Р.Сәгъди

**Этләнә башлау** Билгеле моменттан алып этләнү

**Этләнеп бетү** Бик нык, тәмам этләнү. *Хәбиров, --- үрмәләп, дүрт аяклап, чокырдан чокырга кычкырып, боерык биреп йөрде. Тәмам этләнеп --- бетте.* Х.Камалов

**Этләнеп йөрү** Озак вакытлар этләнү; соңгы вакытта этләнү. *И-и Садыйк абзый, Таһир җиде җир читендә башын салмаса, шулай этләнеп йөри торган хатын мени мин?!* Р.Мулланурова. *Бу сүз аның аңына барып җитте дә, кая керергә урын таба алмыйча, озак кына этләнеп йөрде, аннан соң кире борылды һәм нindидер тыкрыкка кереп югалды.* Шәһри Казан

**Этләнеп тору** Гел, даимән этләнү; хәзерге вакытта этләнү

**Этләнеп яту** *сөйл. к.* **этләнеп тору**. *--- берәр ай --- Аннаны хәл җыйдырырга, аның атналар буе этләнепятуларын туктатып, иркенчәрәк торырга кирәк.* Г.Исхакый

**ЭТЛӘҮ** *ф.* 1) Газаплау, интектерү, җәфалау. *Син чыланып, эштән чыгып кайтасың, ул, хәл сорашып, безгә булышу урынында, ачулы йөз белән каршы чыга да, озын кашларын салындырып: – Йөрисез шунда ат этләп! – ди.* Г.Ибраһимов

2) Кадерсезләп таушалдыру, туздыру, җыйнаксыз куллану. *Күптән түгел генә алган киемнәрен этләгән*

**ЭТЛӘЧ** *и. диал. к.* **этләй**. *Бидәлгә яисә кәрҗингә эләккән балыкны җыясың, кара төстәге этләч балыгын ташлый барасың.* М.Галиев

**ЭТЛӘШҮ** *ф.* Усаллану, явызлану; чаялану, әрсезләнү. *Бернichә кеше, этләшеп, тәки Нуруллаהы колхозга алдырмадылар.* А.Гыйләҗев. *Күптән түгел ул, этләшеп, үз урынына кайтты һәм эшкә кереште.* Р.Кәрами

**Этләшә бару** Торган саен ныграк этләшү. *Каешланып беттем бугай, Этләшә барам һаман: Дүрт ел инде җай чыкканда Язам да язам роман.* Н.Әхмәдиев

**Этләшеп алу** Берара, кыска вакыт кына этләшү. *Кайчагында үземне дә, башкаларны да гадәттән тыш хәлгә куеп этләшеп алырга яратам.* Шәһри Казан

**Этләшеп бетү** Тәмам, бик нык этләшү. *Әлеге шул эт белән этләшеп беткән ишегалды малайлары.* Ф.Хөсни. *Юкса бер-беребез белән этләшеп беттек бит?* Безнең гәҗит

**Этләшеп җитү** Тиешле дәрәҗәдә, җитәрлек этләшү. *Кыскасы, этләшеп җиттем, дөресрәге, эт каешына әйләндем.* Р.Кәрами

**Этләшеп йөрү** Озак вакыт дәвамында, төрле җирдә этләшү. *Тик моннан соң ул Әминнәрегез, Дәминнәрегез этләшеп йөрүләреннән генә туктасын.* Җ.Дәрзаман

**Этләшеп тору** Әле, хәзерге вакытта этләшү; озак этләшү. *Белмәсә, башкалар кебек ыкы-мыкы килеп, этләшеп тормый – такта янына чыкмый ---.* Р.Батулла

**Этләшеп яту** *сөйл. к.* **этләшеп тору**. *Мин дә аның белән этләшеп ята алмыйм, мин ул кешене шәхсән белмим.* Әлмәт таңнары

**ЭТЛЕК** *и.* 1) Кешенең характерындагы явызлык, әшәкелек. *Этлеге һәркемгә билгеле*

2) Берәүгә карата эшләнгән начар гамәл, әшәкелек. *Заманында ул миңа, Баязит абыйга да байтак этлек эшләде, шуңа күрәме мин аны сөймим, ни уйлавымны белмәвен телим...* А.Гыйләҗев. *Бернichә мәртәбә Салихның этлегеннән самавырлары эрегәч, мәдрәсә эченә күзәтче – караул куялар.* З.Зәйнуллин

3) Мутлык, усаллык. *Малайлар, алар нindидер этлек эшләргә җыеналар, күңелем шулай сизә.* А.Гадел. *Бер-бер артлы, күз алдымнан Рушанның, --- бүтән малайларның йөзләре чагылып үтте. Алар шат иде. Үзләре эшләгән этлектән куанышып, көлешеп торалар иде...* Г.Гыйльманов

4) Әрсезлек, үҗәтлек, үзсүзлелек. *Көн итәргә этлек кирәк. Эт булырга күптән оныттым.* Н.Исәнбәт

◊ **Этлегендә булу** Яман кешенең гел яманлык кына эшләве турында. *Хәзер аңа, ышанып, яхшы җирдән кызны ничек бирсеннәр? Начар җирдән*

*алсаң, һаман да шул этлегендә булыр, рәткә килмәс*. Г.Камал. **Этлеген итү** *к*. **этлегендә булу**. *Күрәсең, ул кара җан этлеген иткән: Юматшага әләкләгән...* Г.Әпсәләмов. **Этлеккә салыну** Төрлечә әмәл-хәйлә белән мавыгу. *Казан халкы бөтенләй этлеккә салынган иде. Көндезләрен вак-төяк сату иткән булып маташалар да, кичәләрендә гостиницалар, пивной вә фәхеш урынналарында кичләр үткәрәләр иде*. Г.Исхакый

**ЭТЛЕ́-МӘЧЕЛЕ** *рәв*. Дошманнарча, туктаусыз үзара талашып-ызгышып. *Әти-әниләре, этле-мәчеле булып дигәндәй, үзара шактый еш ызгышсалар да, гомумән алганда, алай начар тормыйлар*. В.Нуруллин. *Шул көннән башлап, күрше белән этле-мәчеле яшибез*. И.Юзеев

◊ **Этле-мәчеле, әрем ачылы** Тынышмыйча, үзара кычкырышып, ямьсез сүзләр әйтеп, талашып яшәү турында. *Берегез уңга чалуласа, берегез – сулга. Этле-мәчеле, әрем әчеле, дигәндәй... Ул да тормыш түгел*. Казан утлары

**Э́ТНИК** *с*. Этнос белән бәйле булган, этноска караган. *Казан ханлыгы халкы этник яктан Кырым ханлыгы, башка татар ханлыклары һәм Нугай урдасы белән бербөтен кавем тәшкил итә*. И.Хуҗин. *--- бер яктан, сүз сәнгате тарафыннан тудырылган әдәби образлар вакыт яки этник чикләр белән бүленеп яшәми, икенчедән, аларның барлыкка килүе, этимологик үзгәрешләре иҗтимагый аң, яшәү рәвеше белән турыдан-туры бәйләнешле*. Д.Абдуллина

**ЭТНО-** *гр*. Кушма сүзләрнең «нинди дә булса этноска, халыкка, милләткә хас» мәгънәсен белдергән беренче кисәге (мәс., *этнопарк, этнопсихология)*

**ЭТНОГЕНЕЗ** *и. гр*. Халыкның, этносның килеп чыгышы. *Бүгенге көндәге татар халкының, шулай ук башкорт, казакъ, каракалпак, нугай, комык һ.б. халыкларның этногенезында (формалашуында) кыпчакларның өлеше гаять зур*. Н.Фәттах. *Әле А.Х.Халиков ук бу тип чыганакларны хәзерге татар халкының этногенезын --- өйрәнгәндә актив фәнни әйләнешкә кертергә тырышып караган иде*. Б.Хәмидуллин

**ЭТНО́ГРАФ** *и. гр*. Этнография белгече. *Танылган тарихчы һәм этнограф Ч.Вәлиханов тәңречелек тарафдарларын XIX гасырда Казакъстанда да очраткан әле*. А.Тимергалин

**ЭТНОГРАФИЗМ** *и. гр*. 1) *лингв*. Аерым бер төбәк халкының тормышкөнкүреш предметы, гореф-гадәте һ.б.ш.ны белдергән диалекталь, әдәби телдә эквиваленты булмаган сүз

2) Китап, пьеса һ.б.ш.ның җирле көнкүреш, гореф-гадәт кебек төрле этнографик детальләрне, гадәттә кирәгеннән артык, эчтәлегенә кереп тормыйча чагылдыру үзенчәлеге. *--- рәссамнар һәм сынчылар Сөембикәне онытмады, качып һәм качырып (этнографизм, типаж дәрәҗәсендә) булса да, аның образын иҗат итте*. Мәдәни җомга

**ЭТНОГРА́ФИК** *с*. Этнографиягә караган, этнография белән бәйле. *700 ел буена сузылган болгар-татар дәүләте чоры бай этнографик культураның барлыкка килү һәм үсү дәвере булган*. Г.Гомәр. *Татарстан Республикасын төзегән вакытта, аның этнографик чикләрен билгеләүдә Г.Шәрәф төзегән картапроект нигез итеп алына*. М.Мәһдиев

**ЭТНОГРА́ФИЯ** *и. гр*. 1) Аерым халыкларның көнкүреше, гореф-гадәтләре, матди һәм рухи мәдәнияте турындагы фән. *Институтның археология һәм этнография секторы мөдире --- профессор Альфред Хәсән улы Халиков биредәге әйберләрнең барысына да кыскача аңлатмалар бирә*. Г.Гомәр. *Әлеге хезмәт тел тарихы, --- этнография, диалектология өлкәләрендәге казанышларны исәпкә алып, шушы һәм башка фәннәр кисешендә барлыкка килгән этнос, тел, мәдәният бәйләнеше ясссылыгында татар исемнәрен өйрәнүне максат итеп языла*. Г.Шәйхиева

2) Теге яки бу халыкның, урынчылыкның көнкүреш, гореф-гадәт, матди һәм рухи мәдәниятендәге үзенчәлекләр җыелмасы. *Ул Идел буе халыкларының этнографиясе һәм фольклоры белән кызыксына икән*. М.Гайнетдинов. *Тел кануннарын һәм үзенчәлекләрен, төрки халыкларның тарихын һәм этнографиясен яхшы белгән --- Н.Фәттах бу мәсьәләне асылда хәл иткән*. Л.Галитзуллина

**ЭТНОКОНФЕССИОНАЛЬ** *с*. Нинди дә булса этносның дине белән бәйле булган, этник һәм конфессиональ факторларга мөнәсәбәтле. *1920 елларга үзләренең аермалыкларын саклап калган керәшен татарлары татар милләте эчендәге аерым этноконфессиональ (яисә субконфессиональ) берлек булып карала ала*. Д.Исхаков. *Җирле халыкның этнографик һәм этноконфессиональ төркемнәренең үсешенә кагылышлы мәсьәләләр тулысынча ачылып бетмәде*. Б.Хәмидуллин

**ЭТНОКРА́ТИЯ** *и. гр*. Хакимият бер генә этнос вәкилләреннән формалашкан элита кулында булган җәмгать строе. *Башкортстан хакимиятенә җитәкчелеккә идеологиясе башка милләтләрне кыралмаучылык рухы, милли-этник асаба башкортчылыкка нигезләнгән этнократия килде*. А.Хәлим

**ЭТНОЛЕКТ** *и. гр. лингв*. Бер үк телнең төрле этносларда кулланыла торган варианты, этник диалект, телнең регионга яки милләткә бәйле варианты. *Караим, кырымчак һәм урум телләре Кырым татар теленең этнолектлары булып санала*

**ЭТНОЛИНГВИ́СТИКА** *и. гр.-лат*. Тел белеменең төрле халыкларның көнкүрешенә, гореф-гадәтләренә, мәдәниятенә һ.б.ш. караган тел чараларын, телнең халык мәдәнияте формалашудагы һәм яшәвендәге конструктив ролен, йогынтысын өйрәнә торган тармагы. *Әгәр этнолингвистикада тел югалту күренеше «деэтнизация» дип атала икән, димәк, тел алыштыру – ул телне югалту гына түгел, ә тел белән бергә милләтне бар иткән башка сыйфатларның да зәгыйфьләнүе дигән сүз*. Фәнни Татарстан

**ЭТНОМӘДӘНИ** *с*. Нинди дә булса этносның мәдәниятенә бәйле, мәдәниятенә караган. *Көчләп ассимиляцияләү Идел-Урал төбәге татарларының эчтән туплануына, үзләренең дини бердәмлекләрен төшенүгә, мөселман этномәдәни гомумилеге тууга китерде*. М.Хәсәнов. *Әмма халык массалары милли идеяләрне пассив рәвештә үзләштерүчеләр генә булмаганлыктан, милли үзаң барлыкка килү процессына реаль йогынты бик күп факторларга, бигрәк тә социаль үзгәрешләр темпына (шул исәптән этномәдәни үзгәрешләргә дә) бәйле була*. Д.Исхаков

**ЭТНО́НИМ** *и. лингв. гр*. Нинди дә булса халык, милләт, кабилә, ыру кебек милли берләшмәнең исеме. *Безгә Кытай чыганакларында «татар» этнонимының «дада», «тата» рәвешендә аталуы хакында синологларның хезмәтләре аркылы билгеле*. М.Әхмәтҗанов. *Зәкиев, тел белгече буларак, этнонимнарны, халык яки кабилә атамаларын өйрәнде*. М.Миначев

**ЭТНОНИ́МИКА** *и. лингв. рус* Ономастиканың этнонимнарның килеп чыгышын, төзелешен, таралышын, кулланылышын өйрәнә торган бүлеге. *Финугор этнонимикасында сипыр дигән*

*угор (ханты-мансиларның ата-бабалары) кабиләсе билгеле.* Р.Әхмәтьянов. *Лингвистик археология борынгыдан сакланган ономастик берәмлекләрне, атап әйткәндә, антропонимиканы (кеше исемнәрен), топонимиканы (җир-су исемнәрен) --- һәм этнонимиканы (кабилә, халык исемнәрен) җентекләп өйрәнә ---.* Фәнни Татарстан

**ЭТНОПАРК** *и. гр.-лат.* Билгеле этносның көнкүреше, гореф-гадәтләре, мәдәнияте белән таныштыру максаты белән торак, остаханә, тегермән һ.б.ш.ның гадәти зурлыктагы макетлары тупланган ачык һавадагы музей һәм ял паркы; этнография паркы. *Этнопарк тирәсенә Россиянең төрле халыклары Кыш бабайлары җыелачак.* Сабантуй. *Этнопарк биләмәсендә тимерчелек, чүлмәк ясау, чигү буенча һөнәри остаханәләр дә булачак.* Ватаным Татарстан

**ЭТНОПСИХОЛО́ГИЯ** *и. гр.* Психологиянең төрле раса һәм халыкларның психикага бәйле үзенчәлекләрен өйрәнә торган тармагы, этник психология. *Аның шигырьләре, иҗтимагый актуальлеккә ия булган күпсанлы поэмалары әхлак, этнопсихология, мифология, милли характер һәм милли үзаң, халык педагогикасы мәсьәләләре белән кызыксынган галимнәр өчен дә кызыклы.* Р.Харис. *Гамәли психология, этнопсихология һәм мәдәниятара аралашу психологиясенең фәнни мәгариф үзәге кайчандыр училище булган җирдә урнашкан.* Казан утлары

**Э́ТНОС** *и. гр.* Уртак тарихи-мәдәни мирас, тел һәм территория белән бәйле кешеләр берлеге (ыру, кабилә, халык, милләт). *Башка эре этнослар кебек үк, татарлар да катлаулы эчке этник структуралы.* Д.Исхаков. *Казан ханлыгы чорында формалашкан чуваш этносы таралган территория Идел буе калкулыгының төньяк өлешен биләп торган ---.* Б.Хәмидуллин

**Э́Т ПЕТРУШКАСЫ** *и. бот.* Чатырчәчәклеләр семьялыгыннан тармаклы сабаклы, ялтыравык яфраклы, петрушкадан иссез булуы белән аерылып торган агулы үлән; *русчасы:* **кокорыш, собачья петрушка**. *Эт петрушкасы – һәркайда бар үлән. Иске йортлар, каралты-кура тирәсендә һәм киртә буйларында үсә.* К.Насыйри

**ЭТТАНА́У** *и. кимс.* Шымчы

**Э́Т ТИГӘНӘГЕ** *и. бот.* Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан вак кына сары чәчәкле, ланцетсыман яфраклы, урман аланнарында, урман читләрендә, куаклыкларда үсә торган берьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* **череда трёхраздельная**. *Агрономия факультетында укучы студентларга, басуларга чыгып, гербарий өчен чүп үлән эзләп йөрисе дә түгел, безнең хуҗалыкның азык цехына гына киләсе. Билчән, әрем, саз камышы, солычә, эт тигәнәге...* М.Садыйков

**Э́Т ТЫРНАГЫ** *и.* Тырнак төбе яргаланып кубудан барлыкка килгән җәрәхәтле теленмә тире, шайтан тырнагы; *русчасы:* **заусенец**. *Карый Нәҗип: эт тырнагы атсыз бармакларына да чыккан... Ул, аяусыз кыланып, үткер тешләре белән эт тырнаклары чүпләргә тотынды...* А.Гыйләҗев. *Әгәр сездә эт тырнагы башланып, авырту һәм шешүгә чыдый алмыйсыз икән, болай эшләгез ---.* Сәламәтлек юлдаш булсын!

**ЭТҮ** *ф.* 1) Нинди дә булса юнәлештә кузгалырга яки күчәргә мәҗбүр итү, урыныннан арырак шудыру, этәрү, тибәрү. *Һади йомылып артка ташланды, хыянәтче иптәшләре аны бозҗрадан чыгармадылар, күкрәкләре белән алга – пыялачыга таба эттеләр ---.* А.Гыйләҗев. *Аркадан салкын җил этә, колагымда Гөлинәнең «Рәхмәт, Айнур» дигән сүзләре яңгырый ---.* А.Мансуров

2) *күч.* Читләштерү, үз араларына алмау, читкә кагу. *Илдар нииндидер юллар белән иптәшләре арасына кереп китә алды әле, ә Ания – юк. Аны «начальник баласы, буржуйка» дип, гел читкә эттеләр.* Р.Габделхакова. *Без үз каһарманыбызны үзебез үк читкә эттек, аннан үзебез үк йөз чөердек хәтта.* Мәдәни җомга

**Этә бару** Торган саен ныграк этү. *Моңа карамастан, милләтче фикерләр, Көнбатыш культурасына нигезләнгән позитив фәннәр иске дини системаны кирегә таба этә бара.* Казан утлары. *Яман булмаган шеш әкрен генә, тән тукымасын этә барып, аны җәрәхәтләмичә үсә ---.* Ютазы таңнары

**Этә башлау** Этергә тотыну. *Җиһангир көчен югалта барган дусты Сашаны бүрәнәгә җайлабрак салды да, --- бер кулы белән тотып, икенче кулы белән бүрәнәне аргы як ярга таба этә башлады.* Г.Әпсәләмов. *Үзе җәһәт кенә матайдан сикереп төште дә арттан этә башлады.* Аманулла

**Этә бирү** Бернәрсәгә карамастан этүне дәвам итү. *Исмәгыйль --- күкрәге белән чәнечкеле чыбыкка килеп терәлде. Артыннан башкалар һаман да этә бирделәр.* Ф.Яхин. *Ир кеше сыйларны егеткә табан этә бирде.* Х.Әпделмәнов

**Этә тору** Бер-бер артлы этү; берәр эш-хәл белән бергә этү. *Сүз арасында Гөлгенә кайнар пәрәмәчләрне иренең алдына этә торды.* Ф.Яруллин. *Эш дәвам итә: башта кечкенә чокырны тутырдылар, вак таш белән комны бульдозер этә торды, аннары, зур бульдозер килеп, күпсанлы куыш-сарайларны җимерә башлады.* Р.Кәрами

**Этә төшү** Бераз, беркадәр этү. *Пар бөркеп торган кайнар ашны этә төшеп, торып басарга мәҗбүр булды ул.* Р.Мөхәммәдиев. *Шәмсүн башта аптырап калды, сынагандай, һәрвакыттагыча үзеннән этә төшеп, аның күзләренә карап торды.* А.Вергазов

**Этеп бетерү** Ахырга кадәр этү; барысын да этү. *Зәнфирә казанга су өстәде, морҗаның юшкәсен этеп бетерде ---.* Ф.Садриев

**Этеп җибәрү** Уйламаганда, кинәт этү. *--- исенә килергә өлгергән Рәфис, кинәт читкә тайпыла төшеп, --- аны үзеннән этеп җибәрде.* А.Вергазов. *Рәдифнең кулларын читкә кактым да, нык кына итеп, үзен этеп җибәрдем.* В.Нуруллин

**Этеп йөрү** Озак вакыт дәвамында этү. *Без һәрвакыт аның коляскасын этеп йөрдек.* Р.Вәлиев. *Бәлки, көтәргә кирәктер, мөгаен, көне буе таш этеп йөри алмаслар.* Ә.Әминев

**Этеп карау** Сынау максаты белән этү. *Сидоров этеп карады, ишек ачылмады.* Г.Әпсәләмов. *Әйдәгез, машинаны этеп карыйк.* Ф.Яруллин

**Этеп кую** Бер тапкыр этү; читкәрәк этеп, шул хәлдә калдыру. *Ул чәй ясый, чәйгә агач кашык белән сөт сала, шикәрне Гәрәй җизни алдынарак этеп куя ---.* Г.Афзал. *– Укучылар күрер, яхшы түгел, – дип, Саматның кулын йомшак кына этеп куйды.* Г.Галиева

**Этеп ташлау** *сөйл.* Кызулык, ялгышлык яки ачу белән этү, көтмәгәндә этү. *Бөтенләй читкә этеп ташламасыннар тагын дип, буш чакларда [шахтёрлар] белән карта уйнаштыргалыйм.* Ф.Хөсни

**Этеп тору** Әле, хәзер этү; һәрвакыт, даими этү. *Ә пресс калаклары туктаусыз әйләнә, тыгыз, дымлы балчык буткасын дүрткел авыз аша өзлексез этеп тора.* А.Гыйләҗев. *Кисеп чыгарганда, күсәкләр алып, агачны аударасы якка этеп торыгыз, өстегезгә ава күрмәсен.* Р.Мөхәммәдиев

**Э́Т ҮЛӘНЕ** *и. бот.* Этүләнечәләр семьялыгыннан кыска сабаклы, алсушәмәхә, ак, сирәк кенә сары төстәге эре чәчәкләре көз ахырында атып, җимешләрен язын өлгертә торган күпьеллык үләнчел үсемлек; кыш чәчәге; *русчасы:* **безвременник**. *Зариф тигәнәк яфрагы өзеп алып, ярасына каплады: – Их, әчетә үзе, шайтан! Эт үләне табып булса икән ул, шуның белән ышкуга, чәчрәп чыккан кан туктый.* М.Хәбибуллин

**Э́Т ШОМЫРТЫ** *и. бот. к.* **кошкунмас**. *Күп кенә кошлар көзен зелпе, кура җиләге, эт шомырты, гөлҗимеш, кабар агачы җимешләре белән тукланалар.* Биология. *Медицинада --- эт шомырты җимешләренең кайнатмаларын, төнәтмәләрен һәм коры экстрактларын файдаланалар.* Урман аптекасы

**Э́Т ЭЧӘГЕ** *и.* 1) *бот.* Уралмасабаклылар семьялыгыннан башка үсемлекләргә сарылып үсүчән, нечкә озын сабаклы һәм туры озын тамырлы күпьеллык чүп үләне; *русчасы*: **вьюнок**. *Әнә ич Миргали абзыйларның бакчасында алабута, билчән, эт эчәге мыжгыган.* Н.Әхмәдиев. *Яңгыр алдыннан эт эчәге чәчәге йомыла...* Н.Гыйматдинова

2) *күч.* Чиктән тыш озын нәрсә (предмет, хәл, күренеш)

3) *күч.* Бик бәйләнчек кеше. *[Саҗидә:] Рәфис, син кайтасыңмы, юкмы? [Рәфис:] Кайтам инде, кайтам. Эт эчәге булдың.* Т.Миңнуллин

**ЭТЮД** *и. фр.* 1) Натурадан ясалган, гадәттә нинди дә булса әсәрнең бер фрагменты, якынча эшләнеше булган рәсем, скульптура һ.б.ш. әсәр. *Әмма күл буеның этюдын ясау өчен, моннан да уңай урынны табу мөмкин түгел иде.* Г.Сабитов. *Экспедициядә бергә йөргән иптәшләренең портретларын ясады. Кайткач, эскизларны, этюдларны тукымага күчерде.* Ә.Моталлапов

2) Берәр мәсьәләнең аерым аспектына багышланган кечерәк әдәби әсәр. *Алардагы гыйбрәтле, хикмәтле фикерләр, мәкальләргә хас булганча, кыска, төгәл, образлы әйтелә, һәм һәр фикер фәлсәфи планда да, шигъри этюдлар формасында да кәгазьгә төшерелә.* Л.Минһаҗева

3) Виртуоз характердагы музыкаль әсәр. *Башта шигырь сөйли, аннары бер мәсәл... Ә икенче көнне этюд уйнап күрсәтә, һәм аны, өченче турга калдырып та тормыйча, шундук училищега алынган дип исәплиләр!* И.Илялова

4) Музыка, театр, шахматта һ.б.ш.да күнегүләрнең бер төре. *Парижда минем дөнья сәяхәте вакытында язып ташланган математик этюдымны һәм кайбер күзәтүләремне басып чыгардылар.* Җ.Тәрҗеманов. *Шахмат этюдын чишү*

**ЭТЮ́ДНИК** *и. рус* 1) Рәсем ясау кирәк-яракларын һәм этюдларны (*1 мәгъ.*) саклау өчен яссы тартма. *Кабул итү бүлмәсендә син торасың, этюднигыңны җилкәңә элгән килеш... Мине йотты минем эш, сине – синең эш...* Р.Харис. *Бүлмәсенә кайтып кергәч, Зуфирә --- күптән кулына алмаган этюднигын ачты.* М.Маликова

2) Этюд ясаганда кәгазь, киндерне урнаштыра торган кечерәк такта; мольберт. *Әлеге искитмәле матур күренешләрдән илһамы кабынып, ул шунда ук этюднигын алды.* А.Хәсәнов. *--- барлык укучы песи баласын тота башлады. Этюдниклар ауды, сулар түгелде.* Гөлшаһидә

**ЭФЕ́ДРА** *и. гр. бот.* Эфедрачалар семьялыгының бердәнбер төре: нык тармакланган, вак кына яфраклы, башакка тупланган вак сары чәчәкле, коры климатлы районнарда үсә торган тәбәнәк мәңгеяшел куак яки ярымкуак үсемлек. *Моннан берничә ел элек Бәйрәкә тауларында нарат ботагы төсле эфедра үсемлекләренең кыпкызыл җиләкләрен күрү бер дә гаҗәп түгел иде.* Социалистик Татарстан

**ЭФЕ́ДРАЧАЛАР** *и. гр. бот.* Бердәнбер төре эфедра булган мәңгеяшел куаклар семьялыгы

**ЭФЕДРИН** *и. гр.* Эфедрадан, шулай ук синтетик юл белән табыла, медицинада дару буларак кулланыла торган психоактив алкалоид. *Узган атнада Казанда Ижаудан килгән ике кешедә 2 килограмм 100 грамм наркотик матдә – эфедрин тапканнар.* Татарстан яшьләре

**ЭФЕМЕРИ́ДА** *и. гр.* 1) *астр.* Кояш, Ай, планета һ.б. күк җисемнәренең күктәге торышын төгәл вакыт аралыгы белән күрсәткән астрономик таблица

2) *зоол.* Көнлекчеләр отрядыннан бер көн генә яши торган күбәләк, бер көнлек күбәләк; көнлекче

**ЭФЕМЕРЛАР** *и. күпл. гр. бот.* Чүл, тундра кебек кырыс шартларда экологик үскәнгә вегетатив чоры бик кыска булган – кайберләре берничә атнада тулы үсеш циклы үтә торган берьеллык үләнчел үсемлекләр төркеме. *Ярымчүл эфемерлары. Дала эфемерлары. Чүл эфемерлары*

**ЭФЕС** *и. нем.* Кылыч, хәнҗәр һ.б.ш. салкын коралның сабы. *--- мин Әзһәр киеп уйнаган киемнәргә чумып, --- шпагамның эфесына ике кулымны да куеп сәхнәгә атылып чыгуым булды, укытучылар да, студентлар да дәррәү көлә башладылар.* Р.Батулла

**ЭФИОП** *и. гр.* Эфиопиядә һәм Төньяк-Көнчыгыш Африкада яшәүче халыкларның һәм кабиләләрнең гомуми атамасы һәм шуларның аерым бер кешесе. *Матур сынлы, бакыр кара тәнле эфиоп бакча гөлләрен карый.* М.Хәбибуллин

**ЭФИР** *и. гр.* 1) Борынгы грек мифологиясендә һаваның иң югары, саф, бернинди катнашмасыз һәм үтәкүренмәле катламы

2) *иск.* Физикада барлык һавасыз пространствоны һәм гадәти матдәләр (молекулалар, атомнар һ.б.) арасындагы буш аралыкларны тутыра дип фараз ителгән матдә

3) Һаваның өске катламы; гомумән радиодулкыннар тарала торган мохит. *Иртән --- татар халкының яраткан дикторы Камал Саттарова күзәтүемне эфир аша бөтен Татарстанга яңгырата.* Г.Гомәр. *Әгәр дә аның тарихына күз салсак, радионың татар-башкорт редакциясе тапшырулары рәсми төстә 1953 елның 11 декабрендә эфирга чыга.* Г.Шәйхи // Шуның аркылы алып барылган радио яки телевизион тапшыру. *Эфир вакытын көтү* // Шуны тапшыру рәвеше. *Ачык эфир. Турыдан-туры эфир*

4) *хим.* Спирттан яки фенолдан алынган үзенчәлекле зәһәр исле, төссез, очучан, янучан органик кушылмаларның берничә классының гомуми атамасы. *Бу караштан мин урындыгыма сеңәргә, боз булып эрергә, эфир булып һавага очарга әзер идем.* А.Хәсәнов. *Ә составында этил эфиры молекулалары булган су исә үзендә «кешеләрне исертергә» дигән «мәгълүмат» саклый.* Татарстан яшьләре

**ЭФИРОМАН** *и. гр.* Эфироманиягә бирелгән, эфирга бәйлелеге булган кеше

**ЭФИРОМА́НИЯ** *и. гр. мед.* Эфирны наркотик сыйфатында куллануга һәвәслек, шуннан гыйбарәт авыру. *Эфироманиягә бирелү*

**ЭФФЕКТ** *и. лат.* 1) Кемнең яки нәрсәнең дә булса берәр кешегә ясаган көчле тәэсире, йогынтысы. *Йорт хуҗасы төнге бакчаның теләсә кемнең һушын җибәрерлек эффект ясаганын үтә яхшы белә иде.* Р.Мирхәйдәров. *Беләсеңме, нинди тәэсир, нинди эффект булачак фоторәсемнән.* Р.Мөхәммәдиев

2) Нинди дә булса эш яки эшчәнлекнең нәтиҗәсе; нинди дә булса сәбәп-

ләрнең нәтиҗәсе. *Бу ачыш --- Идел-Урал нефть запасының составын ачыклауда, --- чималны эшкәртү барышында гаять зур икътисади эффект бирә ---.* Ф.Зыятдинов. *Балалар уйнарга теләмәгән уенны мәҗбүриләп бирү тискәре эффект бирә ---.* Фәнни Татарстан

3) Билгеле бер тәэсир тудыра торган эш-гамәл, чара, алым. *Алар оборона тота. Һәм без, язмыш ихтыярына ташлап калдырылган шул кешеләргә буш әрҗәләр ташлап, тавыш эффекты ясыйбыз.* Ш.Рәкыйпов. *Эзләнү һәм тәҗрибәләр кылу – аның холкына хас сыйфатлар. Ачыктан-ачык сәхнә эффектлары, декорацияләр белән мавыгу – аның өчен чит нәрсә ---.* Казан утлары

4) Физик күренеш. *Әйләнү эффекты*

**ЭФФЕ́КТЛЫ** *с.* **1.** 1) Көчле, гадәттә уңай тәэсир итә торган, сокландыргыч, гаҗәп, матур, күркәм. *Ленизаны буй-сын, төс-бит ягыннан эффектлы диләр.* Х.Камалов. *Сәхнәдә эффектлы чыгыш ясап булмавы да кәефләрне төшергән, әлбәттә.* Кәеф ничек?

2) Кирәкле, уңай нәтиҗәгә китерә торган, үтемле, нәтиҗәле. *Аның ат турындагы хыялын режиссёр аеруча басым ясап, эффектлы алымнар белән күрсәткән.* Р.Батулла. *Мәктәптә класстан һәм дәрестән тыш тәрбия эшенең эффектлы формалары барлыкка килде.* Г.Мөхәммәтшин

3) Тышкы тәэсиргә генә корылган, ялтыравык, эчтәлексез, буш. *Төрле отышлы диалоглар кыстырып җибәреп, эффектлы сүзләр өстәп, шома гына нәрсә оештырырга була.* Г.Бәширов. *Димәк, бу фикер – очраклы рәвештә әйтелгән эффектлы тәгъбир генә түгел, ә халык күңелендә төенләнеп килә торган фикер.* Р.Фәйзуллин

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Көчле тәэсир ясап, тәэсирле итеп; җәлеп итәргә, гаҗәпләндерергә, сокландырырга тырышып. *Озын буйлы, маңгай өстендә бер тотам ак чәчле, әйбәт киенгән Яңгура залда бик эффектлы итеп йөрде.* Г.Әпсәләмов. *– Мин ялган вәгъдәләрдән туйган, – дип, Сәет кулының кабыргасын муенына тидереп алды. Ясалмарак булса да, хәтәр эффектлы чыкты.* Т.Галиуллин

2) Нәтиҗәле итеп, үтемле, файдалы рәвештә. *Башкортлар киң колач белән, эффектлы итеп эшлиләр, татарны да, русны да үзләренә хезмәт иттерә беләләр.* Р.Вәлиев. *Дәресләрдә эффектлы эшли, аның өчен төрле-төрле укыту принципларын, дидактик һәм техник средстволар куллана.* Р.Зарипов

**ЭФФЕ́КТЛЫЛЫК** *и.* 1) Көчле, гадәттә уңай тәэсир итү, соклану уяту үзлеге, эффектлы (*1 мәгъ.*) булу сыйфаты

2) Тиешле нәтиҗә, файда китерә алуы, файдалылык дәрәҗәсе, нәтиҗәлелек. *Ачышның яңалыгы бутиленны таркату процессына эффектлылык китерде.* М.Зарипов. *Бу елларда хезмәтнең нәтиҗәлелеге үсте, техниканы куллануның эффектлылыгы күтәрелде, киң күләмдә төзелеш алып барылды.* Г.Мөхәммәтшин

**ЭФФУ́ЗИЯ** *и. лат.* 1) *геол.* Сыек лаваның кратердан яки ярыклардан җир өстенә агып чыгуы

2) *физ.* Газның вак тишекләр аша үтеп торуы

**ЭФФУ́ЗИЯЛЕ** *с.* Эффузия нәтиҗәсендә барлыкка килгән, магматик. *Эффузияле тау токымы*

**ЭХ** *ы.* 1) Соклану, таң калуны белдерә. *– Эх, безнең урманнарның һавасы! – диде Гали абзый.* Г.Әпсәләмов. *– Эх, киче дә киче соң! – диде тегесе, күкрәкләрен тутырып сулап.* А.Гыймадиев

*2)* Гарьләнү, үкенү, кызгану, шелтәләү һ.б.ш. тойгыларны белдерә. *Эх, шул елларны кире кайтарып була торган булса, Гыйлемхан Ханәфине түгел, Ханәфи үзе башлап аны укырга әгъвалар иде...* В.Нуруллин. *– Э-эх, бер буханка кара ипине күкрәккә терәп кисәсе иде, – дип куйды Женя, касәсен төбенә кадәр ялап.* А.Хәсәнов

**ЭХИНОКОКК** *и. гр.* 1) *зоол., мед.* Кайбер хайваннарның эчәкләрендә паразит булып яши торган тасма суалчаннар классы. *Эхинококк дигән тасма суалчан куыкчыл стадиясендә куыкларының эре --- булуы белән аерыла ---.* Биология: хайваннар

2) Шушы суалчанның хайван һәм кеше органнарында яши һәм күп очракларда авыруга сәбәп була торган личинкасы, корты

**Э́Х-МА** *ы. к.* **эх**. *Аны бүген каталажкадан төрмәгә озатмагайлары, качып котыла алмады бит, эх-ма!..* И.Туктар. *Эх-ма, рәхәт минутлар була дөньяда!* Ф.Сафин

**ЭХОЛОТ** *и. гр.-лат.* Тирәнлекне гидроакустик ысул белән автоматик үлчәү приборы. *Дөнья океаны төбе рельефын системалы рәвештә өйрәнү эхолот уйлап табылганнан соң гына башлана.* Башлангыч география курсы

**ЭҺ** *ы.* 1) Авыртудан, хәлсезлектән һ.б.дан кинәт сулыш алып куюны белдерә. *Мулла сүзен әйтеп бетерергә өлгермәде, мин шул кылычны туп-туры аның күкрәгенә батырдым. Эһ, диде дә шундук баскычка авып төште.* М.Галәү. *Газинурның аякларына тимер таяк белән китереп суккандай булды. Ул эһ итеп куйды, --- башын күтәрде.* Г.Әпсәләмов

2) *к.* **эх**. *Култык астында йөрткән гармунын тез башына куеп, стаканы белән берне күтәрде дә: – Эһ, зәһәр, чукынган!.. – дип сөйләнә-сөйләнә, өй эчен шаулатып, бераз җырлаштырып та алды.* Ф.Яхин. *Эһ син, Яңа ел хуҗасы! «Мин! Мин!» – дип йөреп, Яңа елны харап итә яздың!* Ш.Фәрхетдин

◊ **Эһ дигәндә** *к.* **эһ дигәнче**. *Зур болытлар күк йөзен каплап килә тау-тау булып, Җимерелеп үскән игеннәргә карап, зур яу булып. Эһ дигәндә җиргә каплый сулы, ямьсез юрганын, Кызганып җирдән матур, ак саф кояшның нурларын.* М.Гафури. **Эһ дигәнче** Бик тиз, кыска вакыт эчендә. *Хәер, кызларның күңеле эһ дигәнче үзгәрә дә төрләнә бит ул. Бүген болай, иртәгә – тегеләй.* М.Маликова. **Эһ дияргә өлгергәнче** *к.* **эһ дигәнче**. *Әгәренки киресенчә булса, --- ишекне ачып, болдырга аяк басуга, җир ярылып, эһ дияргә өлгергәнче, ул җәһәннәм чокырына төшеп китәр иде.* Ф.Сафин. **Эһ итәргә дә өлгермәү** Берәр эш-хәл тиз, кисәк булганга, аңа реакция бирергә өлгермәү, аптырап калу. *Шәүкәт абый, янындагы тартмадан шприц алып, аңаниндидер сыеклык тутырды, аннан, эһ итәргә өлгермәдем, Тулганайның күкрәгенә укол энәсен батырды.* Ф.Сафин. **Эһ тә итми(чә)** Бик җиңел генә. *Эһ тә итмичә, бер стаканны каплап куя кияү балакай, икенчесен...* З.Хөснияр. *Тели икән, эһ тә итми, имтиханнан азат итә ала ул сине!* В.Нуруллин. **Эһ тә дими(чә)** *к.* **эһ тә итми(чә)**. *Бибисара түти --- иң юан авыруларны да, эһ димичә, караватка күтәреп сала, төшерә.* Г.Әпсәләмов. *Ә син йөзләгән төп каенны эһ тә димичә кискәнсең дә аткансың.* М.Хәбибуллин

**ЭҺЕ** *ы.* Килешү, раслауны белдерә; әйе. *Кенәз, ягымлы йөзен күтәрә биреп, дикъкать белән тыңлый, эһе, эһе, дип куйгалый.* Х.Камалов. *– Тешегез сызлыймы, Вәсилә туташ? – Эһе, эһе, – дип баш какты кыз.* Н.Гыйматдинова

**ЭҺЕЛДӘ́Ү** *ф.* 1) Авыртудан, хәлсезлектән, көчәнүдән һ.б.ш.дан өзек-өзек сулыш чыгару. *Аның йөзенә сары суккан. --- Ул энекәшләре кебек эһел-*

*дәми дә, ыңгырашмый да, --- өнсезөметсез ята.* Г.Галиев

2) Чарасызлыктан ни эшләргә дә белмәү. *Гали Вәлиевич, ваза үчен алырга теләп, сул кулындагы газетасы белән эһелдәп өстәлгә сукты*. Ф.Садриев

**Эһелдәп алу** Аз гына, бераз эһелдәү

**Эһелдәп йөрү** Шактый вакыт, күптәннән бирле эһелдәү

**Эһелдәп кую** Бер тапкыр эһелдәү. *Халык дулкынлана, гөжли, тораторгач, үзеннән-үзе кычкырып җибәрә, эһелдәп куя*. Г.Бәширов. *Мәгъзүрә карчык еларга җитешеп эһелдәп куя да: «Картлыгымда булса да бер килен рәхәте күрермен, дип хыялланган идем, юк икән, миңа Ходай язмаган икән», – ди.* Г.Галиев

**Эһелдәп тору** Бертуктаусыз эһелдәү

**ЭҺЕМ** *иярт.* **1.** Тамак кыру тавышын белдерә. *Апайлар, җиңгиләр, минем дә хәлемә әзрәк керегез инде, менә... эһем, эһем, тамагым чистый кипте бит, җитмәсә, безгә монда чиләк белән су да куярга онытканнар...* Ә.Еники. *Таяклы кеше эһем, эһем итеп тамак кырды*. В.Нуруллин

**2.** *ы. мәгъ.* Сөйләшкән вакытта кыенсынып калганда, нишләргә белмәгәндә кулланыла. *– Сез, кем, Биккенә... эһем, эһем, – мулла абзый безнең җизни буласының исемен онытып җибәрде, күрәсең, әйтә алмый торды*. Г.Бәширов. *Ибраһим хан фәрештәнең үзен күргән сыман бөтенләй коелып төште: – Кһм, ни, эһем, эһем, ни бит, – дип, авыз эченнән генә ботка пешерде ул.* В.Имамов

**ЭҺИК-МӨҺИК** *ы.* Иркәләнеп чытлыклануны белдерә. *[Камилә:] Бай дигәч тә, --- берсенең дә миннән артык җирләре юк. Кулларыннан бер тиенлек эш килми, көне-төне: «Эһик-мөһик! Әни, башым авырта, --- әни, миңа гармонь итәкле күлмәк тектерик», – дип, кылынып, --- аналарына иркәләнгән булып яталар*. Г.Камал

◊ **Эһик-мөһик килү** Иркәләнеп чытлыклану, кылану. *Сиңа Галиябануның көчле, саф мәхәббәтен гәүдәләндереп бирергә кирәк булачак. Бу сиңа, беләсең килсә, кич белән капка төбендә, берберәүнең кабыргасына төртешеп, эһик-мөһик килү түгел.* Г.Бәширов

**ЭЧ** *и.* 1) Берәр нәрсәнең ябык, тышкы ягыннан күренми торган, берәр нәрсә белән ышыкланган, капланган урыны, түре, уртасы, үзәге; *киресе:* **тыш**. *Көн болытлы булганга, китапханә эче караңгырак иде.* А.Вергазов. *Троллейбусның эче бал исе белән тулды.* А.Хәлим

2) Берәр предметның нәрсә дә булса салырлык, куярлык сыешлыгы. *Хезмәтчесе бер табак эчендә пешкән әтәч китереп, алдына куйды*. К.Насыйри. *Мин язам, шунда күрәм: лампам эчендә май кими.* Г.Тукай

3) Кеше һәм хайваннарда бавыр, ашказаны, эчәкләр, талак һ.б.ш. әгъзалар урнашкан урын; корсак куышлыгы. *Дүртенче стадия – инде ул үлем дигән сүз. Профессор моны Фәкилә апаның эчен ачып карагач та күрде. Ул әле эчне ярып, анда күз салганга кадәр, бәлки, бөтенләй таралып өлгермәгәндер, бәлки, кисеп ташларга мөмкинлек бардыр, дип уйлаган иде.* Г.Рәхим // Корсак куышлыгындагы әгъзалар. *Сугымчылар атларны тота тордылар, тотылган берсен суя тордылар. Шунда ук тиресен тунадылар, эчен алдылар, юан бүкәннәргә салып, җылы итне чаба тордылар.* Н.Фәттах // Гәүдәнең шул турысы. *Картның эченә типте кебек Сайгушев, ләкин бу хәрәкәтне Айгузин күрмәде, ул эчен тотып бөгәрләнде*. М.Хуҗин. *Туйдым мин бу рольдән. Башка кеше уйнасын. Эчкә сугалар, башка сугалар.* Аманулла

4) *сөйл.* Ашказаны, эчәкләр һәм гомумән ашкайнату системасы. *Минем кымыздан сару кайный, эч күбә.* М.Хәбибуллин. *Үзем [мәтрүшкә], аштәмләткеч буларак та, төрле авыруларны, әйтик: үзәк нерв системасын, сулыш юлларын, эч авыртуларын, салкын тигәнне дәвалаучы буларак та хезмәт итәм.* Ш.Фәрхетдин

5) *к.* **эчлек** (*3 мәгъ.*). *Әзер бәлеш эчен табага җәйгән камырга өеп салалар да камырның кырыен күтәреп бөрәләр*. Сөембикә. *Киптерелгән алма кышкы компот, пирог эченә ярап куя.* Мәйдан

6) Киемнең сул ягы; эчлек, астар. *Дәү әни сәүдәгәрләргә заказ буенча бүрек эче тегә ---.* А.Расих. *Башындагы күн фуражкасының эче белән битендәге тир бөртекләрен сөртеп алыр.* Җ.Юныс

7) *сир.* Текст, сөйләм һ.б.ш.ның эчтәлеге, асылы. *Төмәнбаш аңа мөһерләнгән төргәк сузуга ук, Мөхәммәдгәрәй корбанының муенына ташланган көзән елгырлыгы белән хат эченә чумды.* В.Имамов. *--- авылдан чыгып качкан Нәгыймнең --- бүгенгә хәлен без хикәя керешендә күп төрле ишарәләр, образлы кинаяләр аша сизенгән булсак, әсәр эченә кереп киткәч тә, автор сәнгатьчәлекнең ышанычлы юлын ташламый.* М.Вәлиев

8) *күч.* Күңел, йөрәк. *Рәфиснең РАПО башлыгы белән тарткалашуына ул эченнән генә сөенеп утырды.* А.Вергазов. *«Ә нинди таза кеше иде бит! – дип, эченнән уйлап куйды. – Хатыныннан башка кыен булган, күрәсең».* Х.Сафина

◊ **Эч ачу** Ачыну, кызгану, җан әрнү. **Эч бару** *к.* **эч китү**. *Температура юк, эч бармый.* Сабантуй. **Эч бору** 1) Эчәклектә ихтыярсыз спазмнар булу; эч авырту. *Карт фельдшер авыруның караваты янына утырды. – Нәрсә булды, үскәнем? – дип сорады ул, аның йөзенә карап. – Эч бора, Мотаһир абый, – диде хатын, чыраен сытып, тартынып кына*. Р.Кәрами. *Еш кикерү, эч кату, эч бору күренешләренең пальма мае кушылган ризыклар ашаудан килеп чыгуы да исбатланган.* Сөембикә; 2) Ачыну, үкенү. **Эч бушану** *к.* **эч бушау**. *Агылсын ла җырлар – татлы уйлар, Агылсын ла, эчләр бушансын*. Ш.Маннур. *– Ела, ела, эчең бушанганчы ела, үзеңә җиңел булып китәр, – диде.* Акчарлак. **Эч бушату** Кемгә дә булса серен сөйләү, борчылуларын, кайгысын кеше белән уртаклашу, эчне пошырган нәрсәләрдән арыну. *Гомуми палатага күчер син аны, рәхәтләнеп эчен бушатсын, үзе ишеләр белән шау итсен.* А.Вергазов. *Синең янга эч бушатырга, киңәшергә дип керүем.* Х.Сафина. **Эч бушау** Берәрсе белән моң-зарыңны, кайгыңны уртаклашканнан соң җиңеләеп калу. *Син оек бәйләп утырырсың, телевизор карый-карый, хәл-әхвәл сөйләшербез, эч бушар.* Г.Афзал. *Гомере буе йомшак сүз ишетмәгән --- хатын, иренең күкрәгенә борынын төртеп, бик озак үксеп-үксеп елады. --- Хатын үзенең эче бушап, күңеле җиңеләеп киткәнен сизгәндәй булды*. В.Юныс. **Эче елый, тышы көлә** 1) Икейөзле, риялы, монафикъ, хөсетле кеше турында; 2) Эчендәге кайгысын, хәсрәтен башкаларга сиздермәүче кеше турында. **Эче ертылу** Нык ачуы килү, эчтән генә көнләшү, ачудан, көнчелегеннән нишләргә белмәү. **Эче кара, тышы ак** Тыштан яхшы булып кыланган усал, мәкерле кеше. **Эче кыру** *к.* **эче кырылу**. *Мәгарифнең эче кырудан туктаган кебек булды. Надиянең, үзем сөйләшеп карармын, дигән сүзе аңа көч өстәгәндәй итте.* Х.Камалов. **Эче кырылу** Эче пошу, борсалану, борчылу. **Эче кытыклану** Көнчелек, гарьлек хисләре кичерү. *Рәйсәнең анасына «әни» дип эндәшүенә эче кытыкланды.*

Н.Гыйматдинова. **Эченә керү** Төрле мәкерле юллар белән кемнең дә булса серен белү. *Кешенең эченә кереп, ачык йөз, тәмле тел белән сөйләшәм һәм шунда ук аңа пычрак атам.* Н.Гыйматдинова. **Эченә генә салып йөрү** Астыртын гына сынап, күзәтеп йөрү. **Эченә жу керү** Шикләнү, курку, сискәнү. **Эченә килешү** *к.* **эченә май булып яту**. **Эченә май булып төшү** *к.* **эченә май булып яту**. **Эченә май булып яту** Кемгә дә булса нәрсәдер бик ошау, бик ярап кую. **Эченә сыймый йөрү** Куанычтан яисә ачудан нишләргә белмәү. **Эченә төен төшкән** 1) Кайгылы, борчулы; 2) Балага узган. **Эченә шик йөгерү** *к.* **эченә шик төшү**. *Баштарак ниндидер бер укытучы үзенә көндәш була алмас, дип санаса да, тора-бара эченә шик йөгерә башлады.* Ф.Яруллин. **Эченә шик керү** *к.* **эченә шик төшү**. *--- юлга чыкканда гына Шаһбазгали кинәт кенә киреләнә башлады. Аның эченә шик кергән иде.* Х.Ибраһим. **Эченә шик төшү** Шикләнә, икеләнә башлау. *Шулчак Кәүкәбелҗәннәтнең эченә шик төште. Гомере буе мәет кебек йоклаган ире нишләп болай кылана соң әле?* Ф.Садриев. **Эченә шыр йөгерү** Курку, шүрләү, эченә курку керү. **Эчендәген әйтеп салу** *к.* **эчендәген ярып салу**. *Кәримә, шаярткан булып, эчендәген әйтеп салды.* М.Галәү. **Эчендәген әйтеп ташлау** *к.* **эчендәген ярып салу**. *Тафтилов, һаман уйланып, әкрен генә тәмәке көйрәтте. Шулай кинәт ачылып, үзенең эчендәген әйтеп ташлаганга үкенә дә шикелле иде.* Х.Камалов. **Эчендәген тышка чыгармау** Серләрен, борчуларын башкаларга сөйләмәү. *Әмма ләкин эчендәген тышка чыгармады, чөнки дөнья аны уйларын яшерергә өйрәткән иде инде.* Р.Кәрами. *Яши торгач, хәйләсез дөнья файдасыз икәнен нык аңлаган, шуңа күрә, туры сөйләргә ничек кенә яратса да, эчендәген тышка чыгармаска өйрәнгән иде ул.* М.Маликова. **Эчендәген чыгарып салу** *к.* **эчендәген чыгарып селкү**. **Эчендәген чыгарып селкү** Эченә җыелган барлык ачу-үпкәсен я серләрен берьюлы әйтеп бирү. *Чыгыш ясаучылардан бер знакум исә күңелен бигрәк ачып салды: «Хәзер самогон куу да нык җиңеләячәк, авылдашлар!» – дип шәрран ярды, эчендәген бөтенләй чыгарып селкеде ул...* Бөгелмә авазы. **Эчендәген ярып салу** Эчен пошырган бар серен яшерми әйтеп бирү. *Аннары ул эчендәген ярып салды: – Ә безгә бакча бозарга кем рөхсәт бирсен?* Ф.Абдуллин. **Эчендәге тышында** Беркатлы, эчкерсез, киң күңелле, күңелендәген яшерми торган. *Мин үзем эчендәге тышында булган кешеләрне күбрәк яратам.* Г.Әпсәләмов. *Оренбургта булган хәлләрнең берсен дә яшермәде. Эчендәге тышында икән.* С.Поварисов. **Эчендәге тышында, күңелендәге телендә** *к.* **эчендәге тышында**. **Эчендә җаны гына юк** *хупл.* Затлы, сәнгатьчә оста ясалган сурәт яки әйбер турында. **Эчендә кату итеп калдырмау** Үпкәсен, ачуын һ.б.ш.ны яшермичә йөзгә бәреп әйтү. **Эченнән энә алырсың** *к.* **эченнән энә үтәрлек**. **Эченнән энә үтәрлек** 1) Бик ябык; хәлсез. *Никтер эченнән энә үтәрдәй ул юка, зәгыйфь сыерның ашаганы һич тә аш булып йокмый, шундук чүпрәләнеп агып бетә иде.* Л.Хәмидуллин. *Ул белгәндә, эченнән энә үтәрлек, тез буе арык кызчык кына иде ич Толымбикә.* М.Әмирханов; 2) Нечкә билле. **Эчен ярсаң, бер әлиф чыкмас** Үтә надан. *Әлифне таяк дип белмәсә дә, күтәрәдер борынны... Аягында аның ката, муенында була ак яка, Эчен ярсаң, бер әлиф чыкмас, үзе мәгълүмат сата.* Безнең мирас. **Эчеңә кереп ятыр** Ягымлы, йомшак телле кеше турында. **Эчеңә килешер** Файдалы булыр, ярап куяр. **Эчеңә пычак кергере** *карг.* Усал, кеше хакына кергән кешегә әйтелә. **Эчеңә таш булып утырсын** *карг.* Кеше хакын ашаучыга әйтелә. **Эчең ертылгыры** Өзлексез акырып елаган балага яратмыйча, ачуланып әйтелә. **Эчеңне ярып карамаслар** «Үзең әйтмәсәң, беркем белмәс» мәгънәсендә әйтелә. **Эчең чыккыры** *карг.* 1) Кеше хакын басып калучыга, ашаучыга карата әйтелә; 2) *к.* **эчең ертылгыры**. **Эче тар** Хөсетле, көнчелекле, кинәчел. **Эче тырналу** Эченнән генә нык көнләшү. *– Шул аждаһа коткарды бит, су төбендә балыкларга ризык буласы идек, – диде Нурсөя, эче тырналып. Гаҗәп, көнләшү узмый иде.* Н.Гыйматдинова. *Гасыйм белән Сәринәнең Йосыф – Зөләйха кебек яратышуына тирәяктагылар сокланып карый иде, бары тик Заһидның гына аларның җитәкләшеп йөргәненә эче тырнала иде. Дөресе шул: ул көнләшә, кара көнләшү белән көнләшә иде.* Р.Батулла. **Эче умач уа, тышы җәймә җәя** *к.* **эче ялкын, тышы салкын**. **Эче ут, тышы мут** *к.* **эче ялкын, тышы салкын**. **Эче эчкә (аркага) ябышу** 1) Бик нык ачыгу; 2) Бик нык ябыгу. *Сукыр Сабирҗан, аны капшап-капшап карагач: – Яшь икән бахбай, моның эче эчкә ябышкан, ачлыктан ябыккан бу, – диде.* Н.Гыйматдинова. *Бөтен дөньяны басты алайса эче аркасына ябышкан челәннәр...* Безнең гәҗит. **Эче ялкын, тышы салкын** Эчендә нык борчылса да, серен тыштан белдермәү, сер сынатмау турында. *Нигәдер күңел елый... «Эчем ялкын, тышым салкын, сиздерәсем килмиде-е-ер...» Сиздермә, хатын, сиздермә...* Н.Гыйматдинова. **Эч жу итү** Курку, кот очу. *Бәлешем тишелгәч үк эчем жу итеп киткән иде аны...* А.Гыйләҗев. *Мондый көтелмәгән очрашудан Җәбирнең эче жу итеп китте.* Н.Фәттах. **Эч йөзе** Эчке ягы, эчтәлеге. *Автор тарафыннан «тикшерелгән әсәрнең эч йөзен, маһиятен (асылын) ачып бирү, әсәр теле, --- хәятка мөнәсәбәте» мәгълүм мизаннар ярдәмендә бәяләнергә тиешле яклар буларак аерып чыгарыла.* Г.Ибраһимов мирасы һәм төрки дөнья **---**. **Эч кату** 1) Эчәклекнең сирәк бушануы яки тулысынча бушанмавы. *Эчең катса – каражимеш суы, эчең борса, шундук шомырт суы эчертә идек, дип сөйләрләр ие.* А.Хәсәнов; 2) Бик каты, хәлдән тайганчы көлү. *Гөлшаһидәнең көлә-көлә эчләре катып бетте.* Г.Әпсәләмов. *Аннары, аның мәзәкләрен тыңлап, эчем катып көлә идем.* А.Вергазов. **Эчкә җылы йөгерү** *к.* **эчкә җылы керү**. **---** *кышкы бураннарда, күзгә караңгы төннәрдә барак тәрәзәләрендәге тычкан уты кебек кенә җемелдәшкән сүрән утларны күргәч, эчкә җылы йөгерә!..* А.Гыйләҗев. **Эчкә җылы керү** 1) Күшеккәннән, туңганнан соң җылына башлау. *Әнисе пешергән өчпочмакларны исенә төшереп, Сиринә пакетка тыгылды: «Ашыйм әле, эчкә җылы кермәсме?»* Р.Габделхакова. *Акрынлап, тәннең дерелдәп калтырануы басылды, эчкә җылы керде, кайберәүләр хәтта изрәп йокыга оеды.* Ф.Хуҗин; 2) Курку яки борчылудан соң җанда өмет уяну, күңел күтәрелү. *Әсәрең журналда яки китапта басылып, берничә кеше тарафыннан хуплау сүзе ишеткәч кенә эчкә җылы керә, үз-үзеңә ышана башлыйсың.* Ф.Яруллин. *Шулай да эчкә җылы керде: мин түгел, урлаган кеше гаепле ич, шуны аңлый башладылар сыман.* Р.Зәйдулла. **Эчкә җыю** Берәр күңелсез

нәрсәне тышка чыгармау, күңелдә генә тоту, башкалар белән бүлешмәү. *«Ни булды?» – дип сорыйм, әйтми, эченә җыеп бара. Эчкә җыярга ярамый, кеше белән бүлешергә кирәк, эчкә җыйдыңмы – кара кан сава ---.* Г.Ахунов. **Эчкә йоту** *к.* **эчкә җыю**. *Ихтыярсыздан күзгә яшь тыгыла, бик зур ихтыяр көче белән генә кайгыңны эчкә йотасың.* Г.Әпсәләмов. *Сөмсере коелган абзый сер бирми, гарьләнүен һәм ачуын эчкә йота ---.* Р.Кәрами. **Эчкә кату керү** *к.* **эчне кату алу**. *[Егетләр] иң соңгы тизлектә йөгерделәр, бертуктаусыз йөгерделәр. Аның [Һарунның] эченә кату керде.* Н.Фәттах. **Эчкә кату төшү** *к.* **эчне кату алу**. *Тик Фарукҗанның йөрәге барыбер урынына утырмады, эченә кату төшкәндәй тоелды.* Т.Әйди. **Эчкә кату чыгу** *к.* **эчне кату алу**. *Кайткан вакытта мин инде арба төбендә үрле-кырлы сикерүдән дә, эчкә кату чыгудан да курыкмый идем.* Г.Бәширов. **Эчкә керү** 1) Нәрсәне дә булса нечкәләү, җентекләү. – *Безнең ише авыл гыйбадларын агарта аласың, дип әйтүеңме? – Ярар, ул кадәр эчкә кермик.* Р.Кәрами. *[Нәби:] Бу мәсьәләдә шуннан да ары эчкә кермик инде, егетләр.* Р.Төхфәтуллин; 2) Сереңне алу, эчке дөньяңа керү. **Эчкә пошаман төшү** Шомлану, шикләнә, борчыла башлау. *Ике көн көтәм кайтканын, өч көн, инде вертолёт та ике тапкыр килеп китте, ә бу кайтмый да кайтмый гына бит! Эчкә пошаман төште минем.* М.Маликова. *Эчкә пошаман төште: җаны булган адәм шул гомер йоклап ятармы?* Сөембикә. **Эчкә салкын йөгерү** 1) Туңа башлау. *Әтиебез энем белән икебезне, чана башына мул итеп салам түшәп, толыпка төреп утырта иде дә, безнең эчкә салкын йөгергәнче, Тегермәнлеккә әби белән бабай янына алып килеп җиткерә иде.* Безнең гәҗит; 2) Шик төшү, борчылу хисе уяну. *[Немец офицеры] үлекнекедәй яртылаш йомык, хәрәкәтсез күзләре белән безнекеләргә төбәлде. Өч солдатның эченә берьюлы салкын йөгерде.* Ә.Еники. *Алар, тайпылып, юл биреп калдылар. Дөресен әйтергә кирәк, эчкә салкын йөгерде. Биредә сак булырга кирәклеген әни дә кисәтеп куйган иде.* Р.Зәйдулла. **Эчкә салып йөрү** Эченнән генә уйлап, хәтеренә алып, башкаларга белдермичә, әйтмичә йөрү. **Эчкә салып кую** Истә тотарга, онытмаска дип хәтергә ныгытып кую. *Гөлсем апа сабыйның буталганын сизде һәм, бер сүз дә әйтмәстән, эченә салып куйды.* Г.Гобәй. – *Ирдәүкәрәк бугай ул директор кызы, – диде тагын икенче бер вакытны, – чалбарлы тавыкмыни, малайлар булып киенгән. Әбәү, килешми кыз кешегә ыштаннан йөрү. Монысын да эчкә салып куйдым.* Д.Зөбәерова. **Эчкә сары май булып яту** Үтә уңай кабул ителү, күңелгә бик тә хуш килү. – *Синең җөпләп торуың әллә минем эчемә сары май булып ята дисеңме? – Талипның йөзенә тир бәреп чыкты.* М.Кәрим. **Эчкә суык йөгерү** *к.* **эчкә салкын йөгерү**. *Аның сүзләрендә ниндидер шом барын сизеп, минем эчкә суык йөгерә.* З.Зәйнуллин. *Сыек сөттән оетылган салкын катыкны агач кашык белән чөмерә башлагач, эчкә суык йөгерде ---.* И.Сирматов. **Эчкә сыймау** Нинди дә булса тойгы-хисләр көчле, мул булуы турында. *Эчкә сыймый шатлыгым, әй нурлана күз алларым.* Г.Харис. *И Болгарым, мөкатдәс җир, Шушы җиргә тәүге басуым. Эчкә сыймас тойгы-хисләр, Тыя алмыйм йөрәк ярсуын.* Г.Хәйруллин. **Эчкә тимәү** *к.* **эчне тишмәү**. *Бу документлар эчеңә тимәс.* Л.Гыйльми. **Эчкә тию** 1) Артык майлы азыктан эч китү. *Алар күп хәлвә ашауның эчкә тиюен инде беләләр иде...* А.Хәлим. *Мае да, боткасы да эчкә тимәде кебек, изелеп йокладым.* Татарстан яшьләре; 2) Нинди дә булса яхшы, кыйммәтле әйбер күп булмау, кем дә булса андый әйбергә лаек булмау. **Эчкә ут салу** Борчу тудыру, кайгыга дучар итү; уйланырга мәҗбүр итү. *Ә бит «утрау-тыкрыгың» дип, «председатель чакта күрмәгәнне ...» дип, үзе эчкә ут салды башта.* Р.Төхфәтуллин. **Эчкә ут төшү** Күңелдә зур борчылу уяну. **Эч кере саклау** Үч, үпкә саклау, ачу тоту. **Эч китү** Ашказаны эшчәнлеге бозылып, еш һәм сыек итеп тәрәт итү. *Искәндәр шуннан мантымады, әле эче китте, әле тамагы шеште.* А.Гыйләҗев. *Икесенең дә эче китә, башы авырта, хәлләре юк – икесендә дә бер үк чир.* Н.Фәттах. **Эч көю** *к.* **эч яну**. *Ап-ак кардай ап-ак күкрәккәем Хыянәтеңнән синең карайды. Ап-ак күкрәгемнең эче көйде, Йөрәккәем калды күмергә.* К.Булатова. *Ни йорты, ни гаиләсе, ни башкасы булмаган хәлдә Карабай ялан кыр өстендә басып калды. --- Хәсрәте йөрәгенә ут булып чагылды, эче көйде.* Ф.Яхин. **Эч кычкыру** Ачыгудан, авыртудан эчәкләрдән үзенчәлекле тавышлар килү. **Эчне актару** Дулкынландыру, тынычсызлап тору, тынычлык бирмәү. *Дымсу кыр җиле аның эчен актарган моң-зарын таратмый, әйләндереп-тулгандырып, яңадан йөрәгенә сылый иде.* Н.Гыйматдинова. **Эчне кату алу** Каты йөгерүдән яки көлүдән эч авырту. *Күп йөгерүдән Равилнең эчен кату алды ---.* Н.Әхмәдиев. **Эчне катыру** Кызык сөйләп, төрлечә кыланып көлке чыгару, каты итеп көлдерү. *Ул шунда үзләренең хуҗасы Нигъмәт хаҗи дигән бер миллионер картны сөйләп эчебезне катырды ---.* Г.Ибраһимов. *[Бартеньев] әзмәвердәй гәүдәсен кыек-мыек китереп, стройның эчен катыра ---.* С.Шәрипов. **Эчне мәчеләр тырнау** *к.* **эчтә (ач) бүре улау**. *Алар урман аланнарын йөреп әйләнгәннән соң, Ахун туктап калды да: – Тамак ачты, малай! – диде. – Минем дә, – диде Җиһангир. – Эчтә мәчеләр тырмаша башлады инде.* Н.Хәсәнов. **Эчне тишмәү** Зыяны тимәү, ярап кую, кирәкле, файдалы булу. *Намусыма хилаф китермичә әйтә алам: мең сумлык гонорары да түгел (гәрчә мең сум – эчне тишми), --- ә ниндидер ашкынулы эчке бер илһам миңа судьяларны җиңеп чыгарга көч бирде.* М.Галәү. *Бушка чоланыңа өелгән тартма-тартма кәнфит-прәннек, капчык-капчык он, ярма, тоз эчне тишми.* Н.Гыйматдинова. **Эчне тырнау** Эчне пошыру, борчу, хафалау. *Мондагы зиннәтләр тагын Җәннәтнең эчен тырнап алды ---.* Г.Әпсәләмов. *Киткәндә әти белән ачуланышкан идем, хәзер шул эчне тырный.* Х.Камалов. **Эчне чишү** Эч сереңне ачу, сөйләп бирү. **Эч өзгеч** 1) Бик кайгылы, борчулы, ирексездән шомландыра, куркыта торган; 2) Күңелнең иң нечкә хисләренә тәэсир итә алган, үзенә бик нык җәлеп иткән. *Фәкать колагым төбендә әллә нинди, --- искиткеч матур җыр, әллә кайдан килгән бик әкрен вә эч өзгеч музыка чыңлый иде...* Ш.Камал. **Эч өзелү** 1) Бик нык кызгану, йөрәккә якын алу. *Кызганудан эчем өзелеп төшә язды.* Р.-Н.Гүнтәкин; 2) Чиктән тыш борчылу, тынычсызлану, рухи газаплану. *Бөтен дөнья харап булгандай каушыйм, эчем өзелеп, әнкәйне кызганам, муенына сарылып елый башлыйм.* Ш.Камал; 3) *к.* **эчтә (ач) бүре улау**. *Аңа карап, Мотаһир да кушучлап су алды, битен чылатты. Җиңел булып китте... тик эч өзелә. Ашыйсы килә...* Р.Кәрами. **Эч**

**пошу** Эшсезлектән яки әйләнә-тирә кызыксыз тоелганда була торган күңелсезлек сизү; җан тынычсызлану, күңел төшенкелегенә бирелү. *Чыннан да, егетләр, ул чагында дөнья искиткеч күңелсез иде. Кызык табарлык, күңел ачарлык бернәрсә дә юк иде. Кайчакларда үләрлек булып эч поша иде.* А.Шамов. *Атна узды, ай үтте – җавап бирмәде бу. Ә минем эч поша. Күңелгә корт керде хәзер.* В.Нуруллин. **Эч сере** Башкалардан яшерелә торган, үзенә генә билгеле булган нәрсә. *Синең бөтен эч серләреңне сөйләп биргәннәр бит.* Г.Әпсәләмов. *Хәер, мин аның алдында әллә ни кыланып, икейөзләнәнеп тормыйм, беркем белән бүлешмәгән эч серләремне дә яшереп азапланмыйм.* А.Әхмәтгалиева. **Эч сызлану** *к.* **эч яну**. *Стансада безне, сакчы белән жандармскийга кертеп, ике хакын түләттеләр, барачак җиребезгә чаклы билет алдырдылар. --- Моңа минем эчем бик сызланды.* Г.Ибраһимов. *Икенчесе – кәттә татар, Мөһер суга урысча. Эч сызлана, колак тона, Йөрәкне ала телеп.* Р.Батталов. **Эч сызу** Нык кайгыру; ачыну, үкенү, пошыну. *Минем эч сыза, Дәшмирек пышынпышын йөри.* Казан утлары. **Эчтә (ач) бүре улау** Ачыгу, ашыйсы килү, карын бик ачу. *Марат --- кулын игезәгенең иңенә салды да өйгә таба этәрде: – Керик! Рәхимә көтә торгандыр... аш та пешкәндер. – Мин дә нәкъ шулай димәкче идем... Юкса эчтә бүреләр улый.* Ф.Латыйфи. **Эчтә ачу кайнау** Нык ачу килү, ярсу, әмма кешегә белдермәү. *Эчтә ачу кайный, дөбер-дөбер кайный, тик тышка бәрми, кан булып йөрәккә оеша иде.* Н.Гыйматдинова. *Шул егетләргә бирешеп торганга эчендә ачу кайный.* Р.Вәлиев. **Эчтә бүре асрау** Кемгә дә булса усаллык уйлап йөрү, үч тоту, үчегү, ачу саклау. **Эчтә бүре саклау** *к.* **эчтә бүре асрау**. **Эчтә көчек өрү** *к.* **эчтә (ач) бүре улау**. **Эчтә мәче кычкыру** 1) *к.* **эчтә (ач) бүре улау**; 2) Берәрсенең уңышына кызыгу, көнләшү. **Эчтән ашалу** Эчтән сызу, көенү, хәсрәт кичерү, үзен үзе өзгәләү, газаплану. **Эчтән игәлү** *к.* **эчтән ашалу**. **Эчтән беркетү** Үзенә үзе сүз бирү, катгый бер карарга килү. *Инде менә бүген, Булатның чакыртып аңа әйткән сүзе соңында, Җиһангир үзе белән Мансуровлар арасында җепнең бөтенләй өзелгәнен эченнән сизенде ---. «Яңадан ул якка таба минем муеным әйләнмәс!» – дип эченнән беркетте.* Г.Ибраһимов. **Эчтән елый, тыштан көлә** *к.* **эче елый, тышы көлә**. **Эчтән елау** Башкаларга күрсәтмичә, белдермичә борчылу, әрнү, өзгәләнү. *Хатын инде Җәббарны югалткан, инде аны Әсмабикә түшәгендә тоткан сыман --- эчтән елап, Сабантуйга әзерләнде.* Н.Гыйматдинова. *Газиз карт сүзгә кушылмады. Ул эченнән елый иде.* Г.Гыйльманов. **Эчтән йому** Нәрсәне дә булса әйтми калдыру. *Юлдашының сүзгә болай саран булуыннан Шәймәрдән абзый бераз шикләнеп тә куйды. Үз хуҗалыгындагы башка якларны эченнән йомып, сүзне волостька күчерде.* К.Нәҗми. **Эчтән йомылу** Кичерешләрен белдермәү, хисләрен, уйларын үз эчендә саклау, үзүзенә бикләнү, кеше белән аралашмау. *Күзе күрмәгән, күңеле иярләшмәгән берәр хәл була калса, шунда ук югалып, каушап та калучан, тик кечелеклелеге белән эчтән йомылып, моны ул сиңа бөтенләй сиздерми калуы да ихтимал.* М.Рафиков. **Эчтән калтырый, тыштан ялтырый** Тышкы кыяфәте матур булып та, эчтән начар булган кешеләр турында әйтелә. **Эчтән көлү** Башкаларга күрсәтмичә, белдермичә генә көлү, куану. *Рөстәм, бар инде хәзер, туктатып кара дип, эчтән көлде дә икенче якка – Тиктормаслар янына кайтып китте.* Г.Кутуй. *Ә кыз эчтән көлде, масайды: «Җан өрсәң дә, оста, син ташка, таш – таш инде, тере мин – башка!»* Р.Фәйзуллин. **Эчтән куырылу** Берәр нәрсәдән курку, шикләнү, сагаю. *«Әни, бәхетле кеше күрәсең килсә, миңа кара, бүгенге көндә миннән бәхетлесе юк», – дигәч, Шәрифә эчтән куырылып килде.* М.Маликова. **Эчтән сызлану** *к.* **эчтән яну**. *Берничә көннән дусты Нәҗия хәбәре аша больницага килгән әнисе, кызының нинди бүлектә икәнен белүгә, бу юлы да кешечә булмавына эчтән сызланып куйса да, хәл эчендә яткан --- кызын жәлләп, артык сорашмады.* Г.Бәйрәмова. **Эчтән сызу** *к.* **эчтән яну**. *Бер карасанда, ул үз язмышыннан бик канәгать кебек, тик үткен шагыйрь күзләре генә аның матур йөзендә яшерен сагыш билгеләре күрде. «Эчтән сыза, ахрысы», – дип уйлады Муса.* Г.Әпсәләмов. *Дөньяның гаделсезлегенә моңа кадәр дә эчтән сызып йөргән Җәмил тагын бер тапкыр үзалдына сүгенеп куйды ---.* Н.Әхмәдиев. **Эчтән тыну** 1) Дәшмәү, җавап кайтармау, сөйләшмәү. *Шулчак Сабирҗан теленнән тагын да сәеррәк сүз ычкынды: – Алар түгел, эшләгән, тиресеннән чыгардай булып казганган, ил дип кан койган кешеләр хуҗа бу тормышка... – диде ул. Кылый Хәмит дәшмәде, эчтән тынды.* М.Галәү. *Кем белән дә тавышланып йөрисем килмәде. Ни генә булмасын, хәзергә мин эчтән тынарга булдым. Ул да, күрәсең, эчтән тына.* Н.Фәттах; 2) Башкаларга белгертмәү, сер бирмәү. *Әнисә күтәрелеп тә бәрелмәде, Якубның муенына да сарылмады, бары, кырау тиеп шиңгән гөл кебек эчтән тынып, моңсу гына карап басып торды.* В.Имамов. **Эчтән уртын чәйнәү** Нык ачуы килеп тә, ачуын тыю, үзен кулга алып, кешегә сиздермәскә тырышу. **Эчтән яну** Кешегә сиздермичә генә борчылу, кайгыру, газаплану, өзгәләнү. *Әркәшә дә, Зарифуллин да, Гыйззәтуллин да Әлтафиның данына кызыгып эчтән яндылар ---.* М.Мәһдиев. *Талия берьялгызы гына эчтән янды, көйде, шулай да, өметсез шайтан дигәндәй, үзе көн дә Ахиярдан хәбәр көтте.* Г.Галиева. **Эчтә саклау** Серне кешегә әйтмәү, бары үзең генә белү. *Ул сәнгатьле итеп укыганда, мин Тукайның мәхәббәт шигырен яңадан ачтым, әрнүгамьнәрен эчтә саклаган Хәсән Туфан, Сибгат Хәкимнәрнең күңел коесы тирәнлеген тойдым.* А.Арсланов. **Эчтә төен калу** *к.* **эчтә төен яту**. *Әмма, мондый зур эшкә тотынганда, эчеңдәгене әйтмичә, иптәшең белән киңәшләшмичә булмый. – Әлбәттә, эчтә төен калмау яхшы, – дип җөплңде Муса аның сүзен.* Казан утлары. **Эчтә төен яту** Күңелдә онытылмаган, борчып торган, хәл ителергә тиеш нәрсә булу. *Иң зур төен [Галләмнең] эчендә ята әле. Аны чишми һич мөмкин түгел. Әмма җаен табарга, уңай вакытын туры китерергә кирәк.* Ш.Камал. **Эчтә ут кайнау** 1) Бик каты кайгыру, йөрәк яну, хәсрәтләнү. *Эчемдә ут кайный, дөрләп янган учак кебек, шуның, ичмасам, бер очкынын да кәгазьгә төшерә алмыйча гаҗизләнәм.* М.Маликова; 2) Үкенү; 3) Сөю, сагыну, юксыну. **Эчтә шайтаннар утын кисү** *к.* **эчтә (ач) бүре улау**. **Эчтә шайтан утыру** Күңеле мутлыкка, азгынлыкка омтылу. *Ул Иванның эчендә шайтан утыргандыр...* Ф.Баттал. **Эч төшерү** Авыр күтәреп, көчәнеп, эчне авырттыру; өзлегү. *Сугыш чорында йөкле арбаны кендеккә утырткнада эчен төшереп, үзен харап итте.*

Ф.Яхин. *Борынгы заманнарда авыр күтәреп эчен төшергән кешенең аягыннан асып куеп дәвалаганнарын ишеткәне була.* Безнең гәҗит. **Эч уу** Үкенү, кайгыру; көнләшү. *Чынлап та, көтмәгәндә айгырны үз тимерхутыңа, яңа каеш исе аңкып торган үз ызбруйларың белән җигеп кайтып керү үзе ни тора, әкәмәт. Дусың сөенәчәк, дус түгелең эчен уачак.* Ф.Хөсни. **Эч яну** 1) Кайгыхәсрәт эчендә булу, хәсрәт чигү, хафалану, борчылу. *Өметләре акланмаудан үзәкләре өзелде, эче янды.* Н.Әхмәдиев. *Эче янды егетнең, йөрәге сызлады. Кайда басканын да белмичә, клуб ихатасында озак йөрде.* Р.Камал; 2) Берәр кешенең уңышыннан көнчелек уяну, көнләшү, гарьлек хисләре кичерү. *Шулай да бер нәрсәгә эче яна аның: халык аларны көннән-көн ныграк читкә тибә.* Г.Гыйльманов. *Эчми торган бер яшь егет менеп алып, Зәңгәр шәлне сөйгәненең иңенә салды. Эче янды моны күргән чибәрләрнең, «Бу шәльяулык миңа булыр» дигәннәрнең.* М.Саттаров

**ЭЧӘК** *и.* 1) Кеше яки хайваннарның, кош яки балыкларның ашкайнату трактының бер өлеше булган сыгылмалы көпшә рәвешендәге әгъза. *Үрдәк сусыз яшәми, сусыз аның тиресе көпшәкләнә, эчәкләре кибә.* Н.Гыйматдинова. *Сукыр эчәк шартлагандыр, бу кадәр дә үзәкләргә үтеп әрнемәс иде...* Р.Мулланурова

2) Сыек һәм газсыман матдәләрне агызу, үткәрү өчен, резин яки башка сыгылмалы материалдан эшләнгән көпшә; шланг. *Насос бар, эчәк бар, хәзер үк складтан алып киләбез дә көйләп җибәрәбез.* Н.Фәттах. *«Складка шланглар кайткан, иртәгә үк --- дояркаларның барысына да өләшеп чыгам». Райком секретаре да, --- савымчыларга кушылып кычкырып көлеп җибәрәләр. Чөнки резин эчәкләрнең сөткә су кушар өчен генә кирәген барысы да белә.* Р.Кәрами

**ЭЧӘ́К-БАВЫР** *җый. и. к.* **эчкарын**. *Көзгә көннәрдә шул халык суйган мал тирәсендә йөргәләп, эчәкбавырны арзанрак хакка алып, шуны тазартып, кадаклап, базарда сату иткән була.* З.Зәйнуллин

**ЭЧӘ́К-КАРЫН** *җый. и. к.* **эчкарын**. *Хәсби җиңги сыерның эчәккарыннарын чиләкләргә тутырып, су буена юарга бар[ды].* М.Гафури

**ЭЧӘ́ККУЫШЛЫЛАР** *и. зоол.* Тәнендә бердәнбер куышлык – эчәк куышлыгы булган күпкүзәнәкле иң гади хайваннар тибы; *русчасы:* **кишечнополостные**. *Эчәккуышлыларда (гидралар, медузалар, мәрҗәннәр) ашкайнату катлаулырак бара.* Биология

**ЭЧӘКЛЕК** *и.* Эчәкләр (*1 мәгъ.*) җыелмасы; кеше яки хайванның ашкайнату системасының ашказанынннан соң башланып туры эчәк белән тәмамлана торган өлеше. *Май матдәсен танып, май эшкәртә торган ферментлар чыгарырга кирәклеген хәбәр итә торган рецепторлар кешенең эчәклегенә урнашкан.* З.Мифтахов. *--- яңгыр суалчанының ашкайнату системасы авыздан, йоткылыктан, үңәчтән, бүксәдән, мускуллы ашказанынннан, эчәклектән, аналь ачыклыктан тора.* Биология

**Э́Ч-БАВЫР** *җый. и.* 1) *к.* **эч-карын**. *Бүген, бәйрәм алды көннәрендә исә һәр авыл өендә тәмле бәлеш, өчпочмаклар, эч-бавырдан тутырмалар, бөккәннәр пешә.* Татарстан яшьләре

2) *күч.* Күңел, йөрәк. *Ә үзенең йөрәгендә кайнаган барлык кара кайгыларын, күңел көлләрен, эч-бавырын өзгәләгән әрнү энәләрен... – барын-барын менә шушы мәлдә чыгарып түгәсе килә кебек.* С.Поварисов

◊ **Эче-бавыры буталсын** *карг.* Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне бозучыга карата әйтелә. **Эч-бавырына керү** Кемнең дә булса тормышына, шәхси эшләренә тыгылу, күңел серләрен белергә тырышу. *Хатын-кызлар, эч-бавырыңа кереп, Сорашырлар үткәннәреңне ---.* Р.Бикбаев

**Э́Ч-БАШ** *җый. и.* Суелган хайванның башы һәм эчке әгъзалары. *Сыер кадәр сыерның, ике сарыкның эч-башы, тезбаш-тубык сөякләре – барысы да үзләренә калды.* М.Хәсәнов

**ЭЧЕМЛЕК** *и.* Эчү өчен махсус әзерләнгән сыеклык. *--- ул кәрзин өстендәге ашъяулыкны ачып, өстәлгә пешкән ит тулы савыт куйды, икмәк чыгарды, кечерәк кенә чүлмәк белән ниндидер эчемлек утыртты.* И.Хуҗин. *Оста хәрәкәт белән коньяклы шешәнең бөкесе алынды, зәңгәрсу рюмкаларга нечкә агым булып, челелдәп, кызгылт сары эчемлек акты.* А.Вергазов

**ЭЧЕНӘ** *бәйл.* 1) Эш-хәрәкәтнең аталган предметның эчке ягына юнәлгәнлеген белдерә. *Беренче егет хуҗа хатынга ташлана. Хатын, ычкынып, бүлмә эченә кереп китә.* Р.Батулла. *Яшелчәләрне күбрәк вакытта бәлеш эченә салганнар.* Р.Зарипов

2) Эш-хәрәкәтнең аталган нәрсәләрнең арасына юнәлгәнлеген белдерә. *Ул абзый халык эченә кереп китә, әмма Ханбал һаман шул читтән генә күзәтүчеләр арасында кала.* Ф.Яхин

3) Эш-хәрәкәтнең берәр мохит, тирәлекнең уртасына, эчкәреге ягына юнәлтелгәнлеген белдерә. *Актырнак, Әбүзәр абзыйның яраткан ау эте, шул томан эченә кереп югала да тагын килеп чыга.* Г.Әпсәләмов. *Мәрьямнең уйлануларына ияртеп, автор безне дә яңадан-яңа вакыйгалар эченә алып керә.* М.Маликова. *«Волга» җәяүле буран эченә йөзеп кенә диярлек кереп тә китте.* Сөембикә

**ЭЧЕНДӘ** *бәйл.* 1) Берәр эш-хәлнең билгеле вакыт аралыгына мөнәсәбәтен белдерә. *Шушы берничә сәгать эчендә ул күзгә күренеп ябыкты; күзләре батып, күз төпләренә күләгә төште; яңак сөякләре калыкты; ике каш арасындагы сызыгы тирәнәйде.* И.Гази. *Шәрифә әбием гомере эчендә ундүрт бала тапкан.* А.Хәсәнов

2) Эш-хәрәкәтнең берәр нәрсәнең эчке ягында башкарылуын белдерә. *Больницага салганнардыр ахрысы, дип кире борылырга торганда гына, өй эчендә ут кабынды.* Г.Әпсәләмов. *Ут сүнеп, кино өзелгәч, клуб эчендә сызгырыш, кычкырыш, дөбердәтеп аяк тибеш һәм сугыш башлана.* К.Кәримов

3) Эш-хәрәкәтнең билгеле мохиттә, чолганышта башкарылуын белдерә; арасында. *«Син, балдыз, яшьләр эчендә кайныйсың, шул турыда бер аңлашуның чарасын күр», – дип үтенгән иде...* Г.Ибраһимов. *Элек үзе коллектив эчендә хезмәт итсә, хәзер инде бүтәннәр белән идарә итәргә тиеш.* Ф.Яхин

4) Эш-хәлнең нинди дә булса бериш хәлләр, күренешләр чолганышында баруын белдерә; тәэсирендә, йогынтысында. *Мәрьям төнне тагын ут-газап эчендә уздырды.* Н.Фәттах. *Шул утлы гарасат эчендә безнең гаскәрләр батырларча сугыша, һәр сталинградчы: «Безгә Идел аръягында чигенергә җир юк!» – дип, дошманның коточкыч басымына бирелмичә каршы тора.* С.Сабиров

5) Нәрсәнеңдер бериш затлар, предметлар, күренешләр рәтендә булуын белдерә. --- *Бәхәйра әйтте: «Җәүһәрләр эчендә иң кыйбатлысы улдыр, дөрре ятим, диләр», – диде.* К.Насыйри. *Шәкертләр, бу көннән алып, үзләренең милләт эчендә иң кадерле, иң дәрәҗәле бер затлар икәнлекләрен аңлап вә аңлатып, үзләренең иң түбән – теләнчедән дә түбән бер мискиннәр түгеллекләрен күрсәтәчәкләрдер.* Г.Тукай

**ЭЧЕННӘН** *рәв.* **1.** *к.* **эчтән** (*2 мәгъ.*). *«Әнә кем өчен тырышкан икән Яңгура», – дип эченнән уйлап алды Гөлшәһидә һәм тиз генә Диләфрүзне читкә тартты.* Г.Әпсәләмов. *Садыйк абзый, --- кызганып һәм шул ук вакытта яратып, эченнән әйтеп куйды: «Нәрсә белә соң ул мескен. Гомер буе ирем дип, балалар дип яшәде...»* А.Шамов

**2.** *бәйл. мәгъ.* 1) Нәрсәнең дә булса арасыннан. *--- кайбер зуррак чәчәкләр эченнән төклетуралар, тузанга баткан йонлач тәпиләрен көчкә сөйрәп, ава-түнә чыгалар.* Ә.Еники. *Ул арада фельдшер да төште, кемнәрдер, ак бидоннарын тотып, куе агачлар эченнән күренеп торган кое сиртмәсенә таба томырылдылар.* А.Гыйләҗев

2) Эш-гамәлнең нәрсәнең дә булса эчке ягыннан тышкы якка юнәлгәнен белдерә. *Даут сумка эченнән чыккан кәгазь кисәген сеңелесенең борын төбенә китереп селекте.* Ф.Яруллин. *Ун минутлар чамасы вакыт узгандыр, урман эченнән тонык кына эт өргән тавышлар ишетелә башлады.* Г.Гыйльманов

3) Нәрсәнең дә булса икенче нәрсәнең эчке, аскы ягыннан киелү, бәйләнү яки ябылуын белдерә; астыннан. *--- бер чиновник шагыйрьнең тәнәфес вакытында арткы бүлмәдә нәкъ театраль Ленин позасына басып, бер кулын кесәсенә тыгып торганын күргән. Тройкадан (ягъни костюм эченнән жилет кигән), сакалы белән кепкасы гына җитми...* А.Тимергалин. *Кожан эченнән пинжәк кигән, пинжәген каеш белән буган --- иде.* В.Нуруллин

4) Эш-хәрәкәтнең башкарылу мохитен, чикләрен, урынын, арасын белдерә. *Ташлы елгага керәбез дә су эченнән барабыз: овчаркалар суда кеше исен югалта.* И.Юзеев. *Имеш, шул болгарлар, куе урманнар эченнән килә торгач, менә шушы ике инеш арасындагы атауларга җиткәннәр.* Р.Зарипов

5) Аталган зат яки күренешнең бериш затлар, предметлар, күренешләр рәтеннән булуын белдерә. *--- ашханәдә аш пешереп, аны кечкенә кисәк алабута икмәге белән ашап, азрак хәлләнгәч, ташчы Камали --- балтачы Гәрәйне бу ашарга җыелган халык эченнән күзе белән эзләде.* Г.Ибраһимов. *Киләчәктә милләтебез эченнән Тукай кебек дамелланың чыгуын теләп сүзен тәмам итте.* Ил йолдызы: Татар мөһаҗирләре матбугатында Г. Тукай

6) Кем яки нәрсәнең чыганагын, чыгышын билгеләү өчен кулланыла. *Гади кеше булып тоелды ул, халык эченнән чыкканлыгы күренеп тора иде аның.* Ш.Маннур

**ЭЧЕ́-ТЫШЫ** *и.* 1) Нәрсәнең дә булса эчке һәм тышкы яклары. *Болар килгәндә, вокзалның эче-тышы халык белән тулы: бар да йөгерә, кабалана ---.* Г.Ибраһимов. *Ненец башындагы озын колаклы, яшь болан тиресеннән тегелгән эче-тышы йон бүрекне салып кулына тотты.* Р.Кәрами

2) *күч.* Бөтен барлыгы, бөтен ягы; холкы, табигате, гадәтләре. *«Малай минеке түгел», – дип, эче-тышы белән бергә ярсыганга күрә, ул аны онытып та җибәргән иде.* Н.Гыйматдинова. *Мөдәррис – барлык вөҗүде белән, эче-тышы белән, бары-югы белән, чыны-ялганы белән халыкчан шагыйрь.* Н.Гамбәр

◊ **Эче-тышы бер** Саф күңелле, эчкерсез, хәйләсез, ачык кеше турында. *Сәмига минут эчендә кырыкка үзгәрә иде. Әмма ачу тота белми иде, эчетышы бер иде.* М.Әмирханов

**Э́Ч-КАРЫН** *җый. и.* Суелган малның ашарга яраклы эчке әгъзалары. *Чарасыздан кер юарга, кассапларда эч-карын тазартырга вә шуның кебек кара хезмәтләргә керешәләр.* Т.Әйди. *Боланнарның эч-карыны да шунда, кеше күзеннән яшермәгәннәр дә ичмасам.* Ә.Әминов

◊ **Эч-карыны киселү** Ачыгу, ашыйсы килү; ачлык күрү. *Карт ирексездән көлемсерәп куйды. Бигрәк тә өзек, төсе-башы качкан, эч-карыны киселгән заманнарга туры килде шул аның гомер башы һәм, гомумән, язмышы!* А.Хәлим

**ЭЧКӘРЕ** *рәв.* **1.** 1) Нәрсәдән дә булса эчтәрәк, ераграк, читтәрәк. *Финнар да оборонaларыннан эчкәре урнашкан авыр туплардан бертуктаусыз ут яудыралар.* Г.Әпсәләмов. *Дүрт сәгать буена татар-башкорт авыллары аша узганда, бер генә мәчет манарасы да күрмәдек: әллә эчкәре урнашканнар, әллә бөтенләй юклар.* Татарстан яшьләре

2) Бик тирән, ерак. *Калын кашлар астына эчкәре үк кереп поскан кечкенә күзләр, ачу белән ялтырап, Тимерине чәнчеп алды.* Г.Бәширов. *Алары кеше күзеннән бик эчкәре яшеренгәнлектән, мәктәп программасы югарылыгында булса да, физиканы – яктылыкның зур ешлыклы электромагнитик дулкыннар икәнлеген искә төшерергә туры килә.* Татарстан яшьләре

3) Эчкә таба. *Заманында Сәкинә белән менә шушы аланда очрашып, --- сукмак буйлап эчкәре кереп, чәчәкләр җыеп йөргән идек бит инде без.* В.Нуруллин. *Сабир картны ат янында калдырып, Хаҗиәхмәт үзе юлдан эчкәре – кар белән капланмаган шәрә җирләргә кереп чыкты.* Г.Галиев

**2.** *с. мәгъ.* 1) Эчтәрәк урнашкан, түрдәрәк, ераграк булган. *Айбиби күренүгә, ишек яры торган сакчылар айбалталарын читкә алдылар, һәм тәхет ягы ишекләре ачылдылар. Эчкәре ишекләрне ачучылар, Айбиби үтүгә, ишекләрне ябып та куйдылар.* М.Хәбибуллин. *Тини бәк көлемсерәп кенә куйды һәм --- шулай ук эчкәре бүлмәгә кереп китте.* Н.Фәттах

2) Ерак, еpактагы. *Күктимер өерне Озынталның иң эчкәре урынына алып бара.* Р.Камал. *Без чит ил кешеләре өчен башкаланы гына түгел, башка эчкәре шәһәрләрне һәм Россия тарихында беренче тапкыр провинцияне дә ачтык.* Ялкын

**ЭЧКЕ** I *с.* 1) Нәрсәнең дә булса эчендә урнашкан; *киресе:* **тышкы**. *Илүсә, тәмам гаҗизләнеп, каршысындагы тәрәзә янына килде, үрелеп, эчке якка карады ---.* Г.Гыйльманов

2) Йөз ягына каршы якта, сул ягында булган. *Билетның эчке ягына, уртасына ниндидер печать басканнар.* А.Шамов

3) Кешенең эч, күкрәк һ.б. куышлыкларында урнашкан (әгъзалар тур.). *--- калын яры астында ни барын белү өчен, эчәкләргә, башка эчке әгъзаларга кагылырга кирәк, ә моны фәкать тәҗрибәле хирург кына эшли алачак.* М.Маликова

4) Кешенең эчендәге әгъзаларында була торган, эчендәге әгъзаларына хас булган. *Хәзер эчке авырулардан җәфалана, көн дә шифаханәгә бара.* Т.Әйди // Шуларның эшчәнлеге белән бәйле. *Эчке секреция бизләрендәге тайпылышлар нык тирләүгә китерә.* Сөембикә

5) Башка кием астыннан, эчтән кия торган. *Менә шул гонорарларга Зәйтүнә Печән базарыннан ботинкалар, костюм-чалбар, эчке киемнәр алсын.* И.Салахов. *Шул ук Кошкарёв боерыгы буенча, күн курткасын, күнитеген һәм чалбарын салдырып алып, Миңнулланы эчке күлмәк белән эчке ыштаннан гына калдырдылар.* В.Нуруллин

6) *физ.* Пешкәкле цилиндр эчендә ягулык янганнан соң хасил булган энергия исәбенә эшли торган. *Сугышка*

*кадәр үк авылда бәләкәй эчке янулы двигатель дә була.* Р.Зарипов. *Эчке янулы двигательләр сыек ягулык (бензин, керосин, нефть) яки янучан газ белән эшлиләр.* Физика

7) *мат.* Өчпочмакның яки күппочмакның ике күрше ягы белән төзелгән. *Шул ук вакытта бишенче постулатны дөрес дип карыйбыз икән, нинди генә өчпочмакның да эчке почмаклар суммасы ике туры почмакка тигез.* Җ.Тәрҗеманов

8) Аерым бер дәүләт, учреждение, оешма эчендәге эшчәнлеккә караган. *– Сез, йөз алтмыш сигезенче тоткын, – диде өстәл артындагы тирән креслога утырган түрә, --- башын күтәрми генә. – Төрмәнең эчке кагыйдәсен бозган өчен, өч тәүлеккә карцерга ябылган идегез, срок тулды.* И.Салахов. *Бюродагы эчке тәртип буенча, гид программадан читкә тайпылмаска, ягъни клиентлар белән артык үз итеп аралашмаска, аларга үз фикерен такмаска, тормыш-яшәүләре белән кызыксынып, гайрәтләрен чигермәскә тиеш иде.* Н.Гыйматдинова

9) Бер дәүләтнең, җәмгыятьнең, коллективның үз эчендәге, үзенеке. *Совет илен тыштан да, эчтән дә дошманнар сырып алган, тыштагы дошманга караганда, эчке дошманнар мең мәртәбә мәкерлерәк тә, куркынычрак та.* Ф.Сафин

10) Шушы дәүләт эчендә гамәлдә булган, шунда гына алып барыла торган. *Халыкара сәүдәдән тыш, әлбәттә, эчке сәүдә дә яшәгән һәм үскән.* Р.Фәхретдинов. *Кайда ул бүген нәтиҗәле, бөтен ил халкы ишетерлек тәнкыйть, фикерләр төрлелеге, ачык һәм аңлаешлы эчке сәясәт?* Н.Шәрифуллин. *Россиядә бүген бу материалны тагын бер предприятие генә җитештерә. Ул да соңгы елларда тулы куәтенә эшләми, эчке базар ихтыяҗларын канәгатьләндерә алмый.* Фән һәм тел

11) Нәрсәнең дә булса нигезен, мәгънәсен тәшкил иткән, чын асылын чагылдырган, тыштан, беренче карашка күренми торган. *Беләге, йөрәге, эчке матурлыгы, үткенлеге белән яулагандыр ул чибәр кыз мәхәббәтен.* С.Поварисов. *Безнең бөек Сара апабыз шигырьнең тирәндәге мәгънәсен, эчке моңын шулай төгәл тоючан иде.* Н.Хисамов

12) *куч.* Кешенең хис-кичерешләренә, рухи дөньясына караган. *Хәзер исә аның үз эченә кысылып, сыкранып яткан эчке дөньясы тышка чыгарга омтыла. Ул кызара төшкән күзләре белән Хәйдәргә туп-туры карап, беренче мәртәбә шулай кыю һәм иркен сөйләшә иде.* Г.Бәширов. *Бу сүзләр тикмәгә генә, әллә кайдан тирәннән, күңеле төпкеленнән килгән ниндидер эчке сыкрану, хәтта җан ачысы белән ыңгырашу сыман, ачынулы ярсулык белән чыкмады лабаса!* Ә.Сафиуллин

13) *куч.* Күңел халәтен, хисләрне чагылдырган. *[Кыз] ачык, шат елмайды, эчке мәхәббәтле, ягымлы тавыш белән күреште.* Г.Ибраһимов. *Эчтән әрнешеп-әрнешеп елаган бала һәм сузынкы, эчке аһәңле моң белән баласын юаткан ана авазы ишетелә.* Ә.Айдар

**ЭЧКЕ** II *и.* Исерткеч эчемлек, хәмер. *Студент эчке мәҗлесенә мине дә дәште. Мин, эчми торган кеше булганыма карамыйча, бай малае белән яхшырак белешер өчен, бу [тәкъдимне] кабул иттем.* Ф.Әмирхан

◊ **Эчкегә бирелү** Исерткеч эчемлекләрне артык күп куллану, эчкечелеккә сабышу. *Кайчандыр ул да төшеп калганнардан булмаган: техникум бетергән геолог буларак, Түбән нефтен эзләүчеләрнең беренчеләреннән булган. Ләкин соңгы елларда эчкегә бирелеп, түбән тәгәрәгән.* И.Хуҗин

**ЭЧКЕРЛЕ** *с.* Үчле, кинә тотучан, озак үч, ачу саклый торган. *Ул, кискен характеры аркасында, еш кына кешеләр белән бозылыша да торган иде. Әмма эчкерле түгел, ачу сакламый, яңадан, берни булмагандай, дуслыкны яңартырга әзер...* Ә.Еники. *Касыйм абзый – шундый кире вә эчкерле зат, ул башлаган уенын ахырына кадәр җиткерергә, каршы дәшкән көндәшен тезләндерергә, аны чәнчеп алырга ярата ---.* Х.Ибраһим

**ЭЧКЕРЛЕЛЕК** *и.* Эчтә ачу, үпкә саклау, эчкерле булу сыйфаты. *Инде хәлләр бу чиккә килеп җиткәч, ягъни бу сыйфатлар янына куркаклык, эчкерлелек, вак җанлылык һәм карьеристлык хисләре дә өстәлгәч, аның алдында ул бөтенләй чит-ят кеше булып күренә башлады.* С.Рафиков

**ЭЧКЕРСЕЗ** *с.* **1.** 1) Ачык күңелле, гади, беркатлы, хәйләсез, кешеләргә ышанучан. *Таһир аны эчкерсез, беркатлы егет булуы өчен үз энеседәй яратты.* А.Хәсәнов. *Булдыра алсагыз, кичерегез эчкерсез, гади авыл балаларын!..* Р.Кәрами

2) Чын күңелдән булган, саф, риясыз, ихласлыкка нигезләнгән; чын. *Үзеңә эчкерсез мөнәсәбәттәге хатын-кызлардан да мәкер, ниндидер усаллык көтәрлек булгач, дөньяда яшәүнең бер мәгънәсе дә юк.* Г.Тавлин. *Карашында бернинди этлек, явызлык, мәкер юк иде бу егетнең. Тик эчкерсез, самими хисләр генә дә назга сусау.* В.Имамов

3) Файда, табыш алуга нигезләнмәгән, дусларча. *Эчкерсез ярдәм*

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Чын күңелдән, ихластан, бөтен йөрәге белән. *Карчык, эчкерсез сөенеп, утын өемен күрсәтте, мунчага кайсы яркаларның япьтәш булачагын иренмичә аңлатты.* А.Гыйләҗев. *Әллә Алисәнең дөньяны балкытып эчкерсез елмаюыннан, әллә чәчкәләрдән сирпелгән аклыктан бөтен тирә-як шул мизгелдә нурга күмелде...* А.Әхмәтгалиева

2) Файда, табыш алуны күздә тотмыйча, дусларча. *Эчкерсез булышу*

**ЭЧКЕРСЕЗЛЕК** *и.* Саф күңеллелек, хәйләсезлек. *Ләкин элеккеге гадилек, эчкерсезлек, хәйләсезлек юк иде безнең арада.* А.Гыйләҗев. *Үзенең эчкерсезлеге, тыйнаклыгы белән күңелен тартып тора иде ул аның.* В.Нуруллин

**ЭЧКЕЧЕ** и. **1.** Эчкечелеккә сабышкан кеше; исерекбаш; алкоголик. *Нинди көч алып чыгып китте Әнвәрне өеннән? Эчкечене – аракыга, тәмәкечене – тәмәкегә, бозык гашыйкны сөяркәсенә тарта торган көч иде бу ---.* М.Маликова. *Капитан, мастерской мөдирлегеннән алынгач, бөтенләй эчкечегә сабышты.* Р.Камал

**2.** *с. мәгъ.* Эчкечелеккә бирелгән, эчә торган. *Эчкече ирнең хатыны да, анасы да төн йокысы күрми.* М.Кәбиров

**ЭЧКЕЧЕБАШ** *и. к.* **эчкече**. *Рөстәм берәүне дә үтермәгән, ул – эчкечебаш, ул эчеп үлгән.* Һ.Такташ

**ЭЧКЕЧЕЛЕК** *и.* Даими рәвештә һәм чамасын белмичә исерткеч эчемлекләр эчү гадәте, эчү белән мавыгудан килеп чыккан авыру; алкоголизм. *Ирләр --- ялкаулыкның, эчкечелекнең, алдашуның, урлашуның, уйнашның нәрсә икәнен белмәгәннәр дә.* З.Зәйнуллин. *Мин моны наркомания, токсикомания, эчкечелек кебек афәтләрдән яшь буынны, киләчәкне йолып алуның бер ысулы дип исәплим ---.* К.Сатиев

**ЭЧЛӘП** *бәйл.* Нинди дә булса бер урынның эченнән. *Болай, чама белән әйткәндә, шактый юл алдылар шикелле инде. Урман эчләп кенә күпме бардылар...* А.Гыйләҗев. *Бүген генә түгел туган якның Ашкындырып үзенә тартуы, Һәрчак рәхәт шулай, басу эчләп, Ат юлыннан җәяү кайтуы.* Г.Рәхим

**ЭЧЛӘ́Ү** *ф.* 1) *махс.* Киемгә яки башка әйбергә эчлек тегү, беркетү. *Ул җыйнак, эчләп тегелгән, тышлыгының аскы өлеше киндердән, өске яртысы – милли бизәкләр белән чигелгән затлы тукымадан.* Ак калфак

2) Ныгыту, саклау, матурлау һ.б.ш. максатлар белән, берәр нәрсәне эчке яктан тукыма, калай, такта яки башка материал белән каплау. --- *заводларның берсендә ишекне броня белән эчләп бирделәр.* Р.Мирхәйдәров

**Эчләп бетерү** Барысын да, тулысынча эчләү; эчләүне тәмамлау

**Эчләп кую** Эчләнгән хәлгә китерү. *Бу якны да такта белән матур итеп эчләп куйганнар ---.* А.Әхмәтгалиева. *Колхоз биргән йортны әнә ничек матур итеп тышлап, эчләп куйганнар.* Маяк

**Эчләп чыгу** Барысын да эчләү, тулысынча эчләү. *Түбәтәйләрне эчләп чыктым*

**Эчли башлау** Эчләргә тотыну

**ЭЧЛЕ** *с.* 1) Эче билгеле сыйфатка ия булган. *Куыш эчле бик картайган юан каен, як-ягындагы агачларга ботаклары белән ябыша-ябыша, әллә никадәр егылмаска тырышып карады.* Г.Бәширов. *Ул арада булмады, яңа хәбәр таралды: юкәлектә үсә торган сары эчле җир гөмбәсен ашка салсаң, нәкъ тә инде тавык ите тәме килә икән...* М.Мәһдиев

2) Эчлеге (*2 мәгъ.*) булган, эчләнгән; эчлеге билгеле сыйфатка ия булган. *[Гайсә:] Туңып торам, карчык. Теге тире эчле камзулым кайда?* А.Гыйләҗев. *Түбәтәй кызыл эчле иде.* В.Нуруллин

3) Эчлеге (*3 мәгъ.*) булган; билгеле эчлек белән пешерелгән. --- *ике игез кыз, куак астына утырып, баллы кабак эчле өччит ашарга керештеләр ---.* В.Ильясов. *Мин аларга ливер эчле пирожкиларны сузам һәм буфеттагы ыгы-зыгы турында сөйләнеп алам.* Ә.Мушинский

4) *күч.* Билгеле характер һәм әхлак сыйфатларына ия булган. *Дөньяда әллә нинди кара эчле кешеләр була.* А.Гадел. *Әлеге хәлләрдән соң тормышта очраган әшәке эчле түрәләрне гомерем буена, ихтыярсыз, Чатан Газизгә тиңләп карарга гадәтләнеп калдым.* Ш.Алпар

5) *күч. сөйл. к.* **эчкерле**. *Ул баланың никадәр эчле икәнен үзең беләсең.* Г.Камал. *Эчле ул, дип, якын итми, диеп, Уйламагыз мине. Ана сөте белән канга сеңгәч, Үзгәрә алмыйм инде.* Ф.Шәрипова

**ЭЧЛЕК** *и.* **1.** 1) Киемнең яки башка әйбернең эчке ягына тегелә, беркетелә торган тукыма. *Садыйк, әтисе берлә шәһәргә барып, Гайниҗамалга әдрәс камзуллык, төлке аягы эчлек, күлмәкләр, читек-кәвеш, шәлләр алып кайттылар.* Г.Исхакый. *Җыены бергә чалбарны җентекләп карагач, тез турысында эчлек астыннан ниндидер каты әйбер таптылар.* М.Галәү. *Табаны машина баллоныннан әмәлләнгән, мамыктан эчлек ясалган олы ботинкалар астында өзлексез кар шыгырдый.* Р.Кәрами

2) Әйбернең эченә, ике тышлык арасына куела торган нәрсә. *Син хәзер энә тота беләсен, аяк машинасын келтерәткән буласың, эчлек сырасың ---.* Казан утлары

3) Бәлеш, тавык түшкәсе, конфет һ.б.ш. эченә салу өчен әзерләнгән җиләк-җимеш, тәмләткеч яки башка ашамлыклар катнашмасы. *Кәримә камырны җәйде, бәрәңге турап, ит белән аралаштырды да суган турап салды, борыч, тоз сипте. Табаны плитәгә куеп җылытты да камыр салды, эчлекне тутырды, өске камырны каплап, бөтерә-бөтерә ефәк бау кебек ишеп китерде.* М.Хәбибуллин. *Пешекчеләрнең ипи һәм бөккәннәр пешерү өчен күәстәге камырлары кабарды, эчлекләр әзерләнде.* Татарстан яшьләре

**2.** *с. мәгъ.* Кием эченә тегү өчен әзерләнгән, кием эченә тегәрлек. *Эчлек материалларны трафаретлар буенча кисү дә меңнәрчә метр материягә экономия бирә.* М.Максуд

**Э́ЧПОШЫРГЫЧ** *с.* 1) Эчне пошыра торган, кызыксыз, күңелсез, күңел кайтаргыч. *Мусаның тагын бер тапкыр шигъри күренешкә карыйсы килә, ләкин камераның бердәнбер тәрәзәсеннән эчпошыргыч соры күк кисәге генә күренә.* Г.Әпсәләмов. *Идән астыннан әле генә яктыга чыккан зур көпшәк чебеннәрнең, зың-зың итеп, ялкау гына тәрәзә пыяласына бәрелүен хәтерләткән эчпошыргыч сүрән тавыш белән, алар көн мәшәкатьләре, эштәге тоткарлыклар хакында зарланыштылар.* А.Вергазов

2) Ялыктыргыч, туйдыргыч; гел бертөрле, үзгәрешсез. *Сүзләр буранны оныттырды, хатирәләр эчпошыргыч җепшек бураннан көчлерәк булып чыкты...* А.Гыйләҗев. *Болар барысы да – атна саен кабатлана торган эчпошыргыч бертөсле күренешләр.* А.Әхмәтгалиева

**ЭЧТӘЛЕК** *и.* 1) *филос.* Күренеш яки процессның төп мәгънәсен, асылын белдерә торган нигезе. *Бу труппа, артистлар арасында яшәп килгән искелек калдыкларына рәхимсез көрәш ачып, --- «Формасы белән милли, эчтәлеге белән пролетар сәнгать өчен!» дигән лозунгларны күтәреп, шул заманның бөек идеаллары белән мәйданга ташланды...* К.Гыйззәтов. *Әйе, җәйнең теге иң озын көнендә дә очрашу шушы ук эчтәлектә кабатланды.* М.Хуҗин

2) Хикәя ителә торган нәрсәнең кыскача тасвирламасы. *Яңадан бер кат китапның эчтәлеген хәтерләде ---.* Г.Кутуй. --- *ун минут чамасы вакыт узгач, солдат бу фильмның эчтәлеген исенә төшерде.* Р.Кәрами

3) Нәрсәнең дә булса төп мәгънәсе, асылы. *Яңа заман татарлар алдына алар кабул итәргә тиешле, димәк, бөтен милли тормышның эчтәлеген үзгәртергә мәҗбүр итүче катгый таләпләр куйды.* М.Хәсәнов. *Бу яулар чынында XV йөзнең соңгы чирегендә Рус дәүләте белән Казан ханлыгы арасындагы мөнәсәбәтләрнең бөтен эчтәлеген ачып салган.* Р.Фәхретдинов

4) Китапның, кульязманың башында яки ахырында бирелә, бүлекләр һәм аларның битләре күрсәтелә торган исемлек. *Татарча Коръән китабында сүрәләрнең, эчтәлектән тыш, хәрефләр буенча тәртибе, аннары тематик күрсәткеч --- бирелүне дә хупларга кирәк.* А.Тимергалин

5) Нәрсәне дә булса тәшкил иткән, нәрсәнең дә булса эчендә булган нәрсә. *Төенчекнең эчтәлеге конфетмазар шикелле әйбергә охшамый иде.* Ш.Камал

**ЭЧТӘЛЕКЛЕ** *с.* **1.** Эчтәлеккә, эчке мәгънәгә бай. *Тәүфикъ Әйди язмалары, тирән эчтәлекле булу белән бергә, җиңел укылышлы, мавыктыргыч булулары белән дә аерылып тора ---.* А.Гыйләҗев. *Башым катты... Буталып бетмәсәм ярый инде... Ә бит нинди мәгънәле, эчтәлекле әсәр язасы килә...* Г.Каюмов

**2.** *рәв. мәгъ.* Нәрсәнең дә булса мәгънәсен, асылын ачып; нәрсәне дә булса һәрьяклап яктыртып, белеп, аңлап, җентекләп. *Аның зур илһамланып, оста һәм эчтәлекле итеп укыган лекцияләре әле дә хәтердә...* Р.Ягъфәров. *Гомәр ага бик эзлекле саф әдәби телдә, эчтәлекле итеп чыгыш ясады.* Т.Нәҗмиев

**ЭЧТӘН** *рәв.* 1) Нәрсәнең дә булса эчке ягыннан. *Сабир түзмәде, эскәмиягә утырып, кесәсеннән зәңгәр конвертны чыгарды да --- ертты. Эчтән ярты табак чамасы кәгазьгә язылган*

*хат килеп чыкты*. А.Алиш. --- *абзар ишеге кинәт ачылып китте, --- эчтән ачудан кызарынган-бүртенгән Гөлфинур атылып чыкты*. А.Вергазов

2) Күңелдән, уйдан. *Гыйбрәтләрдән торган гомеремдә эчтән әйттем күпме төртмә сүз*. З.Мансуров. *Шунда сине группадагы башка кызлар белән чагыштырдым да эчтән уйлап куйдым: мәйтәм, минеке булырга тиеш бу сылу!* Р.Зәйдулла

**ЭЧҮ** *ф*. 1) Нинди дә булса сыеклыкны авызга кабып йоту. *Кичтән бер шешә кефир эчкән идем*. А.Гыйләҗев. *Сөйләшә-сөйләшә ашадылар, компот эчтеләр*. Г.Галиева

2) Исерткеч эчемлекләр куллану. *Мужыт син, инженер булгач, коньяк кына эчәсеңдер? Аракыдан саруың кайнаса, нигә, табабыз аның коньягын да*. Н.Әхмәдиев. *Хи-и-и, кем эчми соң анда? Тик менә теләсә нәрсә эчәләр. Шунысы куркыта*. В.Нуриев

3) Исерткеч эчемлекләрне күп күләмдә куллану, эчкечелеккә бирелү. *Ул әкрен тавыш белән: – Әтием юк, әни бертуктаусыз эчә, – диде*. А.Нәҗми. *Биреште карт. Күп эчә шул* ---. Т.Гарипова

4) *күч*. Нинди дә булса хәлне кичерү, баштан үткәрү. *Акыллы бул! Кайгы эчеп, хәсрәтләнеп Гел яшәргә димәгән бит*. Р.Миңнуллин // Нинди дә булса хис кичерү, күңелгә алу. *Илһам эчү*

◊ **Эчми исерү** Шатлык, канәгатьләнү хисе кичерү, рәхәтләнү, ләззәтләнү. – *Эчми исердеңме әллә, Юматша? – дип сорады Диләфрүз. --- – Әйе, бәгырем, эчми исердем, тормыш матурлыгыннан исердем*. Г.Әпсәләмов. *Мунчага бара торган сукмак ике яклап үскән чәчәкләрдән бөтенләй тараеп калган икән. Аларның хуш исенә җаннар ләззәтләнә, кинәнә, рәхәтләнә. Эчми исерү дигәннәре менә шушыдыр инде ул*. Г.Галиева

**Эчә башлау** Эчәргә тотыну. *Без тагы берни дә булмаган кеби, бер-беребезгә карашып, сөенешә-сөенешә сөйләшеп, чәй эчә башладык*. Г.Исхакый. *Ары-бире мәгънәсезгә сугылып көннәрен үткәрде ул, шыпырт кына, яшереп кенә эчә башлады*. А.Гыйләҗев

**Эчә бирү** Бернигә дә карамыйча эчүне дәвам итү, озак вакыт эчү. *Болын кадәрле өйдә ялгызы яшәп калды, рәхәтләнеп эчә бирде*. Х.Вәлиәхмәтов. *Инде биш сумлык чикләр офыкның теге ягында калды, ә эчкәннәр һаман эчә бирә, берсе дә, кыйбатсынып, аракы алудан туктамый*. Татарстан яшьләре

**Эчә тору** Эчүне дәвам итү; әлегә эчү. *Акчулпанов белән Нигъмәт казый эчә тордылар, эчкән саен, тагы яманрак кызып, кызарып, исерек тавыш белән Тангатаровка таба ташландылар*. Г.Ибраһимов. *Җәүдәт әнисенә борылып, иңеннән сөйде. – Әни, Наза белән чәй эчә торыгыз сез. Мин хәзер бушыйм!* А.Гыйләҗев

**Эчеп алу** Тиз арада эчү; билгеле бер вакыт арасында эчү. *Бар, тиз генә юынып кил, һәм кофе эчеп алабыз да – институтка!* В.Нуруллин. *Фирмам банкротка чыкты, бик каты эчеп алдым*. З.Хәким

**Эчеп бару** Рәттән, даими, регуляр төстә эчү. *Аракыны безнең белән рәттән эчеп барсалар да, алай әллә ни исермәделәр, сер бүлешмәделәр*. Н.Акмал. *Бер өмете калмады Дәүләтханның. Язып биргән бар даруларны да эчеп барды, укол алды – булмады*. Р.Газизов

**Эчеп бетерү** Барысын да, беткәнче эчү. *Әсма, карчыкның кулыннан алып, берьюлы бөтен суны эчеп бетерә*. Г.Исхакый. --- *ханым ялындырып тормады, --- рюмка биленнән эләктереп алды да төбенәчә эчеп бетерде*. А.Вергазов

**Эчеп җибәрү** Тиз арада, кискен генә рәвештә эчү. *Баланы беразга имезми тор, җанны тынычландыра торган тамчыларны күбрәк тамыз да кайнаган җылымса су белән эчеп җибәр*. Г.Галиева. *Закирҗан калтыранган куллары белән стаканга шешәдән аракы агызып эчеп җибәрде* ---. З.Хөснияр

**Эчеп карау** Тикшерү-белү максаты белән эчү. *Бер эчмәсәң дә, суымны Бер эчеп карар идең. Һавада тургайлар булсам, Туктамый сайрар идем*. К.Булатова. *Аның әле бервакытта да сөт эчеп караганы юк иде, алай да бу ак сыеклыкның бик тәмле икәнлеген исеннән сизенде ул*. К.Кәримов

**Эчеп кую** Бер тапкыр эчү. *Фәләх --- ни эшләвен үзе дә белештермичә, тотты да калган коньякны шешәсеннән генә эчеп куйды*. В.Нуруллин. *Хәлим тагын бераз капкалап алды, әйрән эчеп куйды*. Г.Гыйльманов

**Эчеп тору** Хәзерге моментта эчү; гел, даими эчү. --- *көн дә дару эчеп торырга куштылар*. З.Мәхмүди. *Сыерларның кайсысы күшәп ята, кайсысы су эчеп тора*. М.Яһудин

**Эчеп яту** *сөйл. к.* **эчеп тору**. *Безнең заманнарда авыл ирләре, өчәр-өчәр борынга укмашып, кибеттә эчеп ята иде бит*. Н.Гыйматдинова. *«Тагын берәр җиргә кереп, эчеп ята торгандыр инде, хайван!» – диде*. Р.Сәгъди

**ЭЧҮ́-ТАРТУ** *и*. Даими рәвештә эчү һәм тәмәке тарту шөгыле, эчү һәм тарту гадәте. *Күңелемне нечкәртте, дип һавалана алмыйм, ләкин минем башымнан эчү-тарту кебек былчырак нәрсәләрне алып ташлап, алар урынына милләт мәхәббәте, әдәбият сөю кебек матур мәгънәле нәрсә тутырды*. Г.Исхакый. *Эчү-тартуны ташлагач, хезмәттәшләрем дә миңа сәерсенеп карый башлаганнар иде, тик мин түздем*. И.Шиһапов

**ЭЧҮЧЕЛЕК** *и. к.* **эчкечелек**. *Яхшы, дибез, кыюлык һәм каһарманлык, Каян килде эчүчелек, наркоманлык?* Г.Афзал. *Элек, эчүчелеккә каршы карар чыкканга хәтле, рәхәт иде: кайчан телисең, күпме телисең – рәхәтләнеп чөмер, беркем сиңа бер сүз әйтми иде*. В.Нуруллин

**ЭШ** *и*. 1) Гамәл, хезмәт, шөгыль. *Гариф Ахунов эшчән дә иде, ләкин күзенә арпа чыкты. Шулай итеп, эшнең күп өлеше миңа калды*. С.Ибраһимова. *Чулпан болай изаланып ятуның юньлегә булмавын, бу хәлләрне оныттырырлык берәр эшкә керешергә кирәклеген аңлады*. Г.Гыйльманов

2) Нәрсә дә булса ясау, эшкәртү, җитештерү һ.б.ларга юнәлтелгән практик эшчәнлек. *Уракка чыгар алдыннан, кыр эшләре башланганчы, авылда кыз сорап яучы җибәрү гадәте юк* ---. М.Галәү. *Серле эш ул тимер эше, гыйлем ул, шуңадыр, балаларга «ут эше» балта эшеннән кызыклырак тоела*. А.Тимергалин

3) Эшкәртелә торган, әзерләнү процессында булган нәрсә. *Әйе, Ядкәр, базада безне төп эшебез көтә*. И.Юзеев. *Минем синең белән бүтән сөйләшер сүзем юк, дигәндәй, бүрәнәгә каптырып куйган балтасын алды да бүленеп калган эшен дәвам итте*. В.Нуруллин

4) Сүзгә, фикергә капма-каршы буларак гамәл, практик эшчәнлек. *Ат – тешеннән, егет эшеннән билгеле*. Мәкаль. *Милләт сүз көтми, эш көтә*. Г.Исхакый. *Әйдәгез, иптәшләр, сүздән эшкә күчик. Яшүсмерләр белән эшләүне бер милиция өстенә генә аудармаска кирәк*. Р.Зәйдулла

5) Предприятие, учреждение һ.б.ш.дагы хезмәт вазифасы. *Иң соңыннан гына бу язу машиналары ясый торган заводка өйрәнчек булып эшкә керде*. А.Алиш. *Йорт хуҗасының, Акъялны җигеп, фермага эшкә барган көне иде*. В.Имамов

6) Башкарыла торган гамәл, хезмәт; гомумән берәр өлкәдәге эшчәнлек. *Иптәш Җәләев, фермада культура эшләре ничек икән?* И.Юзеев. *Әдәбиятның, гомумән язу эшенең дәрәҗәсе югары заман бу.* Р.Фәйзуллин

7) Белгечлек, профессия, белемнәр һәм күнекмәләр өлкәсе. *Йосыф Акчура ике ел буена сөргендә булып, анда укыту эшчәнлеге алып бара, хәтта ки хәрби эшен дә дәвам итә.* М.Хәсәнов. *Бу өй Сәгадәтнең генә түгел, минем дә иң яраткан урыныма әверелде. Исәп-хисап, язу-сызу эшләрен мин һәрвакыт шушында кереп башкардым.* Ф.Садриев // Һөнәр. *Мин анда сылау, буяу, ташчы, гранит эшкәртү һөнәрләренә һәм балта эшенә өйрәндем.* В.Нуруллин

8) Башкарылу, әзерләнү сыйфаты яки ысулы. *Элегрәк --- авыл өйләренең купшылары стеналарына киндер тастымаллар, келәмнәр элгән --- булыр иде. --- Барысы да кул эше – килен эше.* Г.Хөсәенов. *Үз группамдагы егетләремне кул эшенә: калфаклар, шарфлар, перчаткалар бәйләргә өйрәттем.* А.Хәсәнов

9) Нинди дә булса эшчәнлекнең нәтиҗәсе, эшләнмә; язма хезмәт. *С.Рахманколыйның хикәяләре турында мин үзем курс эше дә башкардым!* М.Мәһдиев. *Бәйрәмгали бөтен язма эшләргә икеле куйган, күчерергә ирек бирмәгән, әллә нинди хаталар эзләп тапкан.* К.Кәримов

10) Һәртөрле мәшәкать, шөгыль. *Фатихәттәй үзенең бетмәс-төкәнмәс өй эшләре артыннан йөри: әллә базарга, әллә кибеткә чыгып киткән.* Г.Әпсәләмов. *Авыл җирендә эш дигән нәрсә гел чыгып тора, тагын булышырмын.* В.Нуруллин

11) Берәр кеше тарафыннан яки кемнеңдер гаебе белән эшләнгән тискәре гамәл. *Тукай инде куркыныч төшеннән айнып бетте, әмма икенче бер шом аны биләп алды: – Мин беркемгә дә телеграмма сукмадым, Хөсәен дустым. Кем эше икән ул?* Р.Батулла. *--- ул тешнең сынган урынын күрсәтте: – Менә, миңа «тырнак белән дә чиртмәгән» Килдеков эше бу, Хәнифә Вәлиулловна!* В.Нуруллин

12) Шартлар, хәлләр, тормыш, көнкүреш. *Менә бит, уйламаганда эшләр җайланды да китте. Көн дә – өстәмә бер паёк икмәк. Аш та баланда түгел – ит шулпасы, ботка, кайвакытта котлет – староста казанынннан.* И.Салахов. *– Эшләр ничек? Исәнлек-саулыкмы? – Эшләр яхшы, – диде Бибинур. – Ходайның биргәненә шөкер, әкренләп йөреп торам әлегә.* Ә.Сафиуллин

13) Йомыш. – *Мин дә китап ярата идем. «Бозау кебек имәсең, аерып алып булмый!» – ди иде әнкәй эш кушканда.* Ш.Галиев

14) Йөкләмә, бурыч. *Шул өстләренә алган эшне матур иттереп булдырып чыгаруны бөтен күңелемез берлән телимез.* Г.Исхакый. *Икенче взводка тимер юлына разведка ясау, поездларның килү-китү вакытларын өйрәнү һәм миналар кую урынын төгәлләү эше йөкләнде.* Г.Кутуй

15) *юр.* Нинди дә булса вакыйга, факт уңае белән административ, суд тикшерүе; шушындый тикшерүгә караган барлык документлар җыелмасы. *Бүген округ судында татар авылларында булып узган крәстиән чуалышлары һәм төрә үтерүләр турындагы эш каралырга тиеш иде.* М.Галәү. *--- әгәр дә бу мәсьәлә буенча суд эше кузгатабыз икән, фактлар да, шаһитлар да җитәрлек.* Р.Юныс

16) Нинди дә булса эшчәнлек, оешма, аерым факт һ.б.ш.га караган рәсми документлар җыелмасы. *Бездә бит конторфәлән юк. --- Барлык эшебез – шушы яшел тышлы кенәгәдә.* Ш.Мөхәммәдев. *Дәүләт куркынычсызлыгы комитеты архивында сакланган 0354351 нче номерлы эштә теркәлгәнчә (архив номеры 18928), дуслар күбрәк милләт язмышы турында сөйләшкәннәр.* Р.Мостафин

17) Вакыйга, факт, очрак. *Без ул чакны бернинди чигенүләрсез көрәшергә, гомер буе көрәшергә ант иткән идек. Бу эшкә күп булса өч ел вакыт узды, ә син инде чигенүдән оялмыйсың.* А.Расих

18) Вазгыять, хәл, торыш. *Артистлар сугышчылар өчен спектакльләр, концертлар куялар, --- ә фронтта эшләр катлауланып китсә, шундук кулларына корал алып, алгы позицияләргә күчәләр ---.* Й.Вәлитова

19) Күренеш, хәл. *Фашистларның чираттагы бу чыгышлары бездә аларга карата җирәнү һәм нәфрәттән башка берни дә тудырмый. Минем үземне бу мәкаләдәге фашистлар уйдырмасы гаҗәпкә калдырды: аларның һәртөрле пычраклыкка барулары яңа эш түгел.* Г.Тавлин. *Бу нинди эш ул: миннән берәү дә моңа тиклем таныклык сораганы юк иде әле, ышанмыйсыңмы әллә?* Ә.Әминов

20) Мәсьәлә. *Эш болай тора: Искәндәр ахунның, чатан мәхзүмнән башка, тагын Гайшә исемле җитеп килгән кызы да бар иде.* Ә.Еники. *Ул аңа, килеп чыккан бер эш турында киңәшләшер өчен дип, үз янына кире кайтырга атчабар җибәргән ---.* Р.Хәкимов // Мәсьәләнең асылы, нигезе, төп мәгънә. *Сәрвәр апа бабайның сүзен ачыклагач кына, без эшнең нәрсәдә икәнлеген аңладык.* А.Гыйләҗев. *Эшнең асылына төшенеп бетмәгәнен аңладылар булса кирәк, егетләр, көлә-көлә, Хәбирнең колагына ук иелделәр.* А.Әхмәтгалиева

21) Берәүнең гадәте; аның вазифасына караган, бурычы булып торган, шуңа хакы буган нәрсә. *Дошманыңны кеше яллап тукмату шулай ук чын егет эше түгел бит инде...* В.Нуруллин

22) Кемгә яки нәрсәгә дә булса мөнәсәбәт, катнаш. *Бүтән барлык профессия кешеләре ничек теләсәләр, шулай яши алалар. --- Чөнки аларның – башкаларда, башкаларның аларда эше юк. Ә врач... Врач ул үзе өчен генә яшәми, ул барыннан да элек башкалар өчен яши!* Г.Әпсәләмов. *Маһирәнең һәр хәрәкәтен күз уңыннан ычкындырмаган Саҗидә, аларда эшең булмасын әле дигәндәй, --- Гыйззелбанатның кем булуы, нилр эшләве турында бәйнә-бәйнә сөйләргә тотынды.* Г.Галиева

23) Берәр хәлдән чыгу юлы, җай. *Төш авышкан иде инде. Мондый чак кызыну өчен әйбәт түгел түгелен, ультрашәмәхә нурлар аз була, ләкин башка бер эш юк...* А.Тимергалин

24) *физ.* Бер төр энергиянең икенче төргә әверелү процессы. *Энергия әверелеше эш белән үлчәнелә, ягъни эш энергия әверелешенең үлчәмәсе булып тора.* Физика

25) Предприятиеләрдә һәм учреждениеләрдә эшче яки хезмәткәрнең хезмәт вазифасын башкара торган вакыт. *Дәүләт эше эшлисе урынга гаилә борчуы белән эш сәгатеңне уздыр инде.* М.Мәһдиев. *Кармашта тоташ ике сменага сузылган эш көне тәмамланган, төзелеш мәйданы буш иде.* М.Маликова

26) Изафәле тезмәләрдә «йөк күтәрү, ташу, тарту, җайланмаларны хәрәкәткә китерү һ.б.ш. механик эш башкара торган (ат, дөя, үгез кебек терлек)» мәгънәсен белдерә. *Кулакларның малларын бәяләү документлары буенча чыгымнар: төзелешкә – 3978,08 сум, эш терлекләре сатып алуга – 11995 сум, авыл хуҗалыгы машиналары һәм кораллары сатып алуга – 8622,69 сум ---.* Р.Зарипов

27) Изафәле тезмәләрдә «хезмәт итә торган, җитештерә торган» мәгънәсен

белдерә. *Колхозда бер эш кулы фронттагы бер таза солдатка тиңләшә торган ел – сугыш елы иде.* Н.Фәттах. *Егерме тугызынчы елда туган ир балалар, күз өстендә каш шикелле, авылның өмете, эш көче иде бит!* С.Зыялы

28) Изафәле тезмәләрдә «билгеле эш төре, күбрәк иҗат яки һөнәр белән шөгыльләнү өчен хезмәт итә торган (бүлмә, кабинет һ.б.ш.)» мәгънәсен белдерә. *Беренче катта Иван Васильевичның йокы бүлмәсе һәм ике эш бүлмәсе, ул аларны беренче, икенче кабинет дип әйтә иде.* Г.Галиева

29) Изафәле тезмәләрдә «рәсми документ булып торган, документлар әйләнешенә караган» мәгънәсен белдерә. *Соңгы үтенечем: зинһар, бу хакта газета материалына караган кебек карамагыз, эш кәгазьләрегез янына да теркәп куймагыз.* Г.Ахунов

◊ **Эш анда түгел** Төп сәбәп башка, икенче төрле. *Ачмы син, ялангачмы – эш анда түгел, иң әһәмиятлесе – син иректә.* М.Мәһдиев. *Давытның куллары хәлсезләнеп салынып төште: Мирхуҗинга ачу саклауда мәгънә юк, чөнки эш анда түгел, эш Нурханованың үзендә, дип уйлады ул.* М.Маликова. **Эш барып чыкмау** Тиешле максатка ирешә алмау, эш кирәкле нәтиҗә бирмәү. *Сәгыйдә көшел өстеннән бер нәзек салам кисәгеен алды да --- егетне кытыклый башлады. Хәкимҗан моны тоймагандай түзеп ятты. Болай эш барып чыкмагач, Сәгыйдә аның ачык күлмәк изүеннән күкрәгенә бодай бөртекләрен коеп уйнарга мәҗбүр булды.* Н.Хәсәнов. *Арлардан исерткечне күпләп сатып алып, урыслар авылларга килгәч, исертеп тотарга кирәк аларны. Әгәр инде бу эш барып чыкмаса, алтын биреп, үзләрен сатып алырга гына кала безгә.* З.Зәйнуллин. **Эш башка** Мәсьәлә, хәл алдагыга охшамаган, икенче төрле. *Китап буенча, синең ашавың харам була инде хәзер. Менә сугышка барып кергәч, анда инде эш башка. Хет гел чучка гына ашап яшә, бер гөнаһы да булмас.* З.Зәйнуллин. **Эш башында** 1) Җитәкче вазифасында, идарәдә. *Төрле дәрәҗәдәге эш башында утырган идарәчеләрнең мотлак күпчелеге татар телендәге матбугатны укымый.* Р.Фәйзуллин. *Тагын берничә дистә елдан төзелештә дә, партия, дәүләт оешмаларында да эш башында социологлар, идеологлар утырачак!* Р.Вәлиев; 2) Нинди дә булса вакыйгада төп роль уйнаучы, әйдәүче, юнәлеш бирүче; лидер. *Бәхетле халыкларда, милләтнең тарихи көпчәге әйләнә башлаган чакларда эш башында торыр өчен, кечкенә булса да саф, пакь, идейный бер милли гөруһ мәйданда була.* Г.Исхакый. *[Нигъмәт:] Тарих бер урында тормый, Габдуллаҗан әфәнде. Бүген алар булса, иртәгә эш башында безнең булуыбыз да бик мөмкин.* К.Тинчурин. **Эш башыннан** Эш хакын эшләнгән эш хисабыннан, эшнең күләменә карап түләү турында. *Өй салучы osталарга акчаны эш башыннан түләргә дип сөйләшенде.* М.Хәсәнов. **Эш бугазга терәлү** Эш бик күп булу, вакыт үтә тыгыз булу. *Ә монда эшләр тәмам бугазга терәлгән: чәчүне бетерәсе, водокачканы ходка җибәрәсе.* Ш.Камал. **Эш булсын дип** Күңел биреп, намус белән, яхшы итеп, җиренә җиткереп. *«Авылым сандугачы»на икенче рецензия – Барлас Камаловныкы. Шулай ук иренмичә, эш булсын дип эшләгән.* Э.Шәрифуллина. **Эшем иясе** *к.* **эшем кешесе** *Карпович --- эшем иясыдәй, кәгазь җилфердәтеп утырды да, кузгал дигәндәй, кабина ишеген япты.* С.Шәрипов. **Эшем кешесе** *ирон.* Кулыннан эш килми торган, әмма эшләгәндәй булып, ыгы-зыгы килеп йөрүче. *--- эшем кешеседәй бөтенесенә кысылып, ашханә һәм амбар ачкычларын чылтырата-чылтырата тыз-быз йөргән ефрейторның --- кәкре балтырларына карап --- елмаеп та куя.* А.Тимергалин. **Эшемне кырган кешедәй** Бик әһәмиятле, әллә нинди зур эш эшләгән кыяфәттә, артык эреләнеп. **Эшем төшмәгән** «Эшем аңа бәйләнмәгән, аңа ялынычым юк» дигән мәгънәдә кулланыла. **Эшен бетерү** Үтерү. *Асылгәрәй карт --- үзенең әле яңа гына үлемнән калганын аңлады. Ул арада Сарбай, тау мәчесенең эшен бетереп, картның аяк очына килеп ятты.* Ф.Бәйрәмова. **Эшен китерү** Берәр эшне шәп итеп, җиренә җиткереп эшләү; берәр нәрсәне бөтен шарты белән үтәү (тиргәү, кыйнау һ.б.ш. тур.). *[Әфганнар] бик сугышчы халык. Бер тотынсалар, инглизнең эшен китермичә бер дә туктамаслар.* Г.Камал. **Эш җанлы** Эшкә җанын биреп эшләүче, эш яратучы. *Асылхан бу бәндәнең --- эш җанлы, олы ниятле, --- эш өчен җаныпкөеп яшәүчән --- бер кеше икәнлеген --- сизенгән иде инде.* Х.Мәхмүтов. **Эш йөртү** Берәр максатка ирешү өчен төрле ысуллар куллану, кешеләр белән сөйләшеп, килешеп хәл итү. *[Нәҗия:] Син соң пленнан ничек котылдың? [Әсфан:] Җизни мондагы начальстволар аша эш йөртеп кайтартты.* Т.Гыйззәт. *--- хәзерге яшьләр --- югары уку йортларына йөзәр мең түләп керәләр! Хәтта --- мин белгән берничә бай миллион сум төрттеләр ректор һәм эш йөртә белүче профессорларга.* Ф.Баттал. **Эш каеру** Күп, зур, әһәмиятле, кирәк эшләр башкару. *– Я, Әхмәт, үзең ни эшләр каерасың? Һаман союзда эшлисеңме әле? – диде [Каюм].* Ш.Камал. **Эш калдырып** Вакытны юкка, бушка, файдасызга әрәм итеп, башкаларның эшенә комачаулап. *Юк, кемнәрдер уйлаганча, эш калдырып, гәп сатып утыру түгел бу, бу – иҗади атмосфера.* Р.Фәйзуллин. *Капка ачылып ябылган тавышны ишеткәч: «И Ходаем, тагын шул Сәвия карчык кереп киләдер инде. Керсә чыга белми, йөри шунда эш калдырып», – дип сөйләнә-сөйләнә, Әлфия ишеккә таба атлады.* Асылъяр. **Эш качмас** Үзе эшлисе килмәгәндә яки башка берәүне эшен куеп торырга өндәп әйтелә. *– Ә эш? Аны мин берүзем эшләрменме? – Эш качмас, бүре түгел.* И.Хуҗин. *Йортта утын әрдәнәсен кардан арчып, тәртипкә китереп ятканда, Давыт янына Хабул килде. – Әйдә, эш качмас, прәннек белән сыйлыйм.* С.Лашманчы. **Эшкә ашу** Нәрсә булса да тормышка ашу, берәр эш барып чыгу. *Бомбежка-фәлән була калса дип алдан төзелгән план хәзер эшкә аша башлады.* Г.Әпсәләмов. *Ниһаять, беркөнне үзенең эшкә ашмас хыяллары белән классны аптыратып бетерә торган Юныс: – Таптым! Тәки уйлап таптым! – дип, дуслары янына йөгереп килде.* Ф.Яруллин. **Эшкә ашыру** Нәрсәне дә булса булдыру, эшләү, тормышка ашыру, үтәү. *Мин көчем җиткән кадәр һәркайсының үтенечендә җавап бирергә, аны эшкә ашырырга тырышам.* Г.Әпсәләмов. *--- башта Птенцов өчен дә Бартеньевның әзрәк иманын укытырга иде. Моны ничегрәк эшкә ашырасын ачык кына күз алдына китермәгән Билалов ротаны тезәргә кушты ---.* С.Шәрипов. **Эшкә бату** *к.* **эшкә чуму**. **Эшкә бирелү** *к.* **эшкә чуму**. *Тиз арада ул эшкә бирелеп китте: аңа шушылай җир өстеннән чалгы белән печән чабып барудан да --- мавыктыргычрак берни юктыр шикелле тоелды.* Н.Фәттах. **Эшкә җигү** 1) Нин-

ди дә булса максатларда файдалану, куллану. *Мин төйнәлгән йодрыкларымны эшкә җигә алам, ягъни сугыша алам.* Р.Батулла. *Мин сездә калган ни бар сабырлыкны эшкә җигәм хәзер.* К.Тимбикова; 2) Эшкә тарту, җәлеп итү; бик нык, тулы көченә эшләтү (кешегә карата). – *Ярамый, Локман бабай, ярамый, сине дә эшкә җиксәк, оятыбызга көч килер, – диләр.* Ә.Еники. *Укуын ташлавын белгәч, бригадир аны рәхәтләнеп эшкә җигә башлады.* Ф.Яруллин. **Эшкә кертү** 1) Файдаланырга, кулланырга яраклы итү, файдаланырлык, кулланырлык хәлгә китерү, эшкә яраштыру. *Читтән килгән иске машиналарны таратып куйганнар, яңадан төзәтеп эшкә кертәчәкләр.* Г.Камал. *[Кабанов:] Иптәш Шәйхетдинов, әгәр дә ул тегермәнегез минем кулга эләксә, эшкә кертер идем мин аны!* Т.Гыйззәт; 2) Эшкәртү. *Бик йомшак булма. Мин китсәм дә, игеннәрне калдырмый эшкә кертергә тырыш.* М.Гафури. **Эшкә кул бармау** Эшләү теләге булмау, эшлисе килмәү. *Берәүнең дә эшкә кулы бармый, өстәвенә электр кабеле сафтан чыгып, барлык аппаратура туктап калды.* А.Тимергалин. *Бүген шалтыраттым – бүген Идиятуллин булмый, диделәр. Шуларга шалтыратасы булгач, бүтән эшкә кул бармый.* Ф.Яруллин. **Эшкә күмелү** *к.* **эшкә чуму**. *Элек Катя, эшкә күмелеп, ашарга да, эчәргә дә онытa иде.* Г.Әпсәләмов. *Урынбасар булса да, ул беркемнең дә урынын басып алырга омтылмый. Бөтен дөньясын онытып, эшкә күмелеп яшәү аның стихиясе.* Ф.Яруллин. **Эшкә чуму** Эш белән бик нык мавыгу, мәшгуль булу, бирелеп эшләү. *Аның --- күңелендә таплы эз булып, яра булып торган кайбер нәрсәләрне оныту өчен, бөтенләе белән чын эшкә, зур эшкә чумасы килде.* Н.Фәттах. *Рушад эшкә чумган, көн-төн китаплар белән.* М.Мәһдиев. **Эшкә яраклы** 1) Эшкә сәләтле, хезмәт итәргә хәленнән килә торган. *Немецлар шәһәрдәге эшкә яраклы кешеләрнең исемлеген алдылар.* Т.Гыйззәт. *Авылда эшкә яраклы ир-егетләр фронтка китә тордылар.* Т.Нәҗмиев; 2) Файдаланырга, кулланырга мөмкин булган. *Мунчала чыгару тел шартлату гына түгел. Әүвәл шул эшкә яраклы юан кайрылы юкә агачларын сайлап куясы --- була.* Т.Галиуллин. *Шул чүп-чар арасыннан энҗе бөртеге табарга тырышып шактый азаплангач, бер мәкаләдән эшкә яраклы киңәш табылган кебек булды.* М.Маликова. **Эшкә ярау** 1) Берәр эш башкарырга яраклы булу, файда китерү; файдаланууга китү. *Утырттык, дим шул, мин дә эшкә ярадым: әзер буразнага орлык ташлап йөрергә.* Г.Якупова. *Инде бернигә ярамый дигән чүп тә эшкә ярап куя: аны карьерларга тутыра-тутыра, --- шуның өстенә уңдырышлы туфрак өстәп, яшелчә һәм җиләк-җимеш үстерәләр.* Э.Халидов; 2) Бик файдалы, урынлы булып чыгу. *Элек --- карый дип, аны авыз ачарга --- чакыралар --- иде. Шул чакта җыелган акча хәзер Баязитка эшкә ярады.* Г.Ибраһимов. **Эш кешесе** Кайда да булса эшләүче кеше; хезмәт кешесе. *Эш кешесе булмагач, районга да теләгән вакытында бара ала.* А.Гыйләҗев. *Мин шәһәрдә сыймыйм, мин – җир кешесе, эш кешесе!* Д.Булатова. **Эш кубару** 1) *к.* **эш кузгату**; 2) Билгеле бер максат куеп, шуны гамәлгә ашыру нияте белән нидер эшләү. – *Солтангир абый, исәнмесез! – Исәнме, исәнме! – диде Шәйгазамов, шатлыктан балкып. – Ни эш кубарып йөрисең?* Р.Кәрами. **Эш кузгату** 1) Бик катлаулы, авыр яки кирәкмәгән эш китереп чыгару, башлап җибәрү. *Өйләнәсе кеше өйләнми, зур эш кузгатмый.* Г.Бәширов; 2) *юр.* Тикшерү эше ачу, тикшерү алып бара башлау. *Суд дигәннән, анасы, мин болайрак уйлап торам әле. Андый-мондый эш кузгатырга уйласалар, егетне яклашырга кирәк, мәйтәм, хәзер закун үзебезнең кулда ---.* Ф.Яруллин. **Эш күрсәтү** 1) Нинди дә булса өлкәдә уңышлы, нәтиҗәле эшләү. *Каюм Насыйридан соң Таиб мулла һәм Габделгалләм Фәезханов, халык әдәбияты җыюда аның эзеннән китеп, кулларыннан килгән кадәр эш күрсәттеләр.* Г.Рәхим. *Күпме еллар авыл советы рәисе булып йөрде, дөресрәге, утырды, юньле эш күрсәтмәде ---.* З.Мурсиев; 2) *к.* **эш кыйрату**. **Эш кыйрату** *ирон.* Берәр эшне булдыру, башкара алу; нәрсә дә булса эшләү, майтару. *Юкка яздым: «Көлеп үләрмен!» – дип, Юк, үләсе килми, егетләр! Күпмени соң әле эш кыйраттым, Күпмени соң әле яшәдем?!* М.Җәлил. *Алга таба беренче класслар-да башта сынау дәресләре, аннары «чын» дәресләр кертеп, бик зур эш кыйрата башламакчылар иде дә...* З.Мифтахов. **Эш кылу** Берәр нәрсә эшләү. *Аркылы ятканны торкылы борсаңчы, Акыллым, берәр эш кылсаңчы, «Мин әйбәт, мин әйбәт, мин әйбәт!» дип, Көн саен ант итеп торганчы.* Г.Афзал. *Ә синең үз гомереңдә фәтвалы эш кылганың булдымы?* З.Хәким. **Эш кыру** *к.* **эш кыйрату**. *Наилә коелып төште, Сабит ашыкмады, зур эш кыргандай, стакан арты стакан «Шифалы су» эчте, кереш сүзсез-нисез энесенең тетмәсен тетәргә ябышты.* А.Гыйләҗев. *Ул күз төпләреннән булмаган яшен сыпырып булашты да, эш кырган кеше шикелле, ян сәкедә торган сөт чиләгенә барып ябышты.* Г.Гыйльманов. **Эшләр уңайга бару** Вазгыять әйбәтләнү, эш җайга салыну, алга китү. *Хәзер, кайтып, редакциягә керештереп йөри башладым. Болай эшләр уңайга бара кебек.* Ф.Яруллин. **Эшләр уңайга китү** *к.* **эшләр уңайга бару**. *[Гөлҗиһан:] Әле менә бүген мәскәүләр белән килешмәкче булып йөриләр. Шулар белән килешеп, эшләр уңайга китсә, тагы ни булса да, ул булыр иде.* Г.Камал. **Эш муеннан** Эш бик тыгыз, бик күп. *Эш муеннан! Әнә тагын бер ресторанга индивидуаль проект төзергә кирәк.* М.Маликова. *Минем мулладан гайре дә эш муеннан. Терлекләр ач, сыерлар саумаган, халык һаман баш төзәтә, айнымый ---.* Н.Гыйматдинова. **Эшне зурга җибәрмәү** Берәр эш-гамәлнең тискәре нәтиҗәсен, вакытында чарасын күреп, мөмкин кадәр киметү, артык зыян китерергә бирмәү; зыян китерүчене гафу итү. *Иртәгесен адвокаты шылтырата: «Эшне зурга җибәрмәгез инде, – дип ялына. – Хатыныгызның, суд юлларында йөреп, мир алдында рисвай буласы килми», – ди.* М.Маликова. *Теге чакта син тимер сукаң белән дә матавык чыгарып аптыраттың безне. Ярый әле эшне зурга җибәрмәделәр.* Р.Низамиев. **Эшне көйләү** Эшне үз файдаңа хәл итү. *--- председатель өстәлдәге хромкага ымлап: – Берәр көй уйнап җибәр әле, – диде. --- Урынбасары белән булган низагтан соң, председательнең үзе белән эшне көйләр өчен, Ходай үзе биргән җай иде бу.* Ә.Баян. *Чынлап еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга, ди, эшне көйләдем бит тәки. Ашап-эчкәч, юк йомышны бар итеп, ветеринар абзыйны фермага җибәрдем.* М.Әмирханов. **Эшнең төбе** Мәсьәләнең асылы, эчке мәгънәсе. *Тагы өч-дүрт көн үткәч, эшнең төбе Галим абзыйга да беленде.* Г.Исхакый. *Эшнең төбе дүрт кабиләнең арасындагы берлекне саклауда һәм менә шул ике урта-*

*дагыларны үз ягына аударуда иде.* Г.Ибраһимов. **Эшне сүтү** Булган я булырга торган эшне бозу. **Эшне тиз тоту** Нәрсәне дә булса тиз, ашыгыч, кыска арада башкару, эшләп чыгу. *Председатель булып килгәч, ул эшне тиз тотты: ике ай дигәндә алты почмаклы якты йорт җиткезделәр.* А.Гыйләҗев. *Алар, җәт-җәт, як-якка карана-карана, эшне тиз тотарга керештеләр. Арба өстенә менеп баскан Зәбир кулындагы капчыклар, берсе артыннан берсе тулып, әрҗә төбенә тәгәрәде.* Н.Хәсәнов. **Эшне юлга салу** Берәр ситуацияне, хәлне төзәтү, көйләп-җайлап җибәрү, тиешле рәвешкә кертү. *Бу кешене командировкага җибәреп кенә, без эшне юлга сала алмадык.* И.Юзеев. *--- әгәр син безгә ярдәм итеп, безнең эшне юлга салырга дисең икән, иң башта син минем автарититны күтәрү чарасын уйла.* В.Нуруллин. **Эш өсте** 1) Җәй көне кызу кыр эшләре (печән чабу, ашлык уру һ.б.ш.) вакыты. *Ике-өч көн элек колхоз печәнгә төшкән иде. Кызу эш өстендә улының вакытын бушка уздырып --- йөрүен Миңнисәттәй бик үк килештереп бетермәде.* Н.Фәттах. *Алар авылга көтмәгәндә, бөтен кеше басуда чакта, кызу эш өстендә килеп керделәр.* Г.Гыйльманов; 2) Эшнең әледән-әле булып ала торган тыгыз вакыты. *Авылда эш бервакытта да бетеп тормый. Иртә яздан кара көзгәчә. Кайчан гына кайтсаң да, берәр «эш өстенә» туры киләсең ---.* Ә.Баян. **Эш пешерү** Эшне булдырып чыгу, хәл итү. *Нәҗип Мәскәүгә киткәч, Гөлнара Наиләнең кылын тартып карады: «Эш пешереп буламы бу чи кабартма белән, юкмы?»* А.Гыйләҗев. *Бу кыланчык тәкәббердән башка да эш пешереп булыр, минемчә.* Н.Сәйяр. **Эш пешү** Эшхәлләр теләгәнчә, уңайга хәл ителү; эш уңышлы барып чыгу. *Сөмбел белән никахлашуны ул яшертен эшләде. Эш пешкәч, алма авызга төшкәч, карт хатынны ризалату авыр булмас.* Ф.Яруллин. *Рәшидә белән улы кушканнарны үтәргә йөгерделәр ---. Хуҗалар, болай булгач, эш пешә, дип елмаешып карап тордылар.* Ә.Хәсәнов. **Эш ташлау** Оешкан төстә, массалы рәвештә эшне туктату, эштән баш тарту, эшкә чыкмау; стачка, забастовка. *Әгәр дә, халыкны котыртып эш ташлатуыгыз һәм рәискә буйсынмавыгыз хакында эчке эшләр бүлегенә хәбәр итәм икән, беләсезме сезне нәрсә көткәнен*? Алга. **Эштән бушатылу** Эш урыныннан чыгарылу, вазифасыннан алыну, эштән куылу. *Моның нәрсә икәнлеген өлкәннәр хәтерлидер: партбилетыннан язган кеше мотлак рәвештә эштән бушатыла, башкача ул гомердә дә җаваплы вазифага урнаша алмый.* З.Мурсиев. **Эштән чыгару** 1) Вазифасыннан азат итү, хезмәт иткән урыныннан алу. *Машинаның шофёр ягындагы ишекне ачуы, каты итеп сүгенүе һәм: – Бүтән күземә күренмә, сине эштән чыгардым! – дип җикерүе ишетелде Робертның ---.* Ф.Баттал; 2) Файдалануга бөтенләй яраксыз хәлгә китерү; туздырып бетерү; сафтан чыгару. *Каһәр суккан, китапны эштән чыгарып бетергән.* Г.Исхакый. *Бәрәңгене, таптап, эштән чыгарып бетергәннәр.* Ф.Садриев; 3) Бик каты, хәлдән тайдырганчы кыйнау. *Аннары тагын сорау алдылар, тагын эштән чыгарып кыйнадылар, аңын җуйгач кына, камерага илтеп ташладылар.* Г.Әпсәләмов; 4) Арыту, талчыктыру, хәлсезләндерү; дәртне, теләкне сүрелдерү, сүндерү. *Кайберәүләр андый хатыннан аерылып котылмакчы була. Ләкин ансат кына котылыйм димә, хатын сине тәмам эштән чыгарып бетерә.* Х.Камалов; 5) Пычрату, ямьсезләү, таушалдыру. *--- коеп яуган яңгыр астында барып, ул өс-башын, аяк киемен эштән чыгарырга мөмкин иде.* Ф.Бәйрәмова. **Эштән чыгу** 1) Авыруга әйләнү, зәгыйфьләнү, җәрәхәтләнү, гарипләнү; зарарлану, зыян килү. *Тузып эштән чыктыңмы, беркемгә дә кирәгең калмый...* М.Хәсәнов. *Хәсән белән Хәлимәсен көтә-көтә, бу араларда тәмам эштән чыккан нервылары бушанып, билләре бераз язылып, сызлаулары кимеп китәр иде шикелле.* В.Нуруллин; 2) Алҗу, аптырау, тилмерү; ару, талчыгу, хәлсезләнү. *Кышкы төнне үткәрә-үткәрә арып бетеп эштән чыккач, өстемә киенеп, йортка чыктым.* Г.Исхакый. *Малларга түбә саламнарын ашатып бетерделәр. Хуҗалык маллары да тәмам эштән чыкты.* Р.Батулла; 3) Зәгыйфьләнү, начараю, бетүгә якынлашу. *Саргая башлаган игеннәр, үләннәр тәмам эштән чыгып, янып-көеп беттеләр, ләкин яңгыр яумады.* М.Гали; 4) Файдаланырга яраксыз хәлгә килү; тузу; җимерелү. *Толып Фәләхетдиннең --- кар базыннан тутыгып тәмам эштән чыккан зур сәгать табыла.* А.Тимергалин. *Тегеләрнең өс-башлары эштән чыккан, аяккуллары сыдырылып-тырналып беткән.* Ш.Шәйдуллин; 5) Пычрану. *Бер тапкыр Илдар комбайн астында шулкадәр аунады, өйгә кайтып кергәндә, бердәнбер пиджагы, тәмам эштән чыгып, автолга буялып беткән иде.* Г.Гобәй; 6) Хур булу, юлдан язу. *Ашап-эчеп, исереп эштән чыгып йөрмәсә, без бит инде аны күптән тотып өйләндергән булыр идек.* Г.Камал. **Эш терәлү** 1) Вакыт, срок җиту. *Галләметдингә Садыйк картның монда булганлыгын үз теле белән әйтеп бирергә эш терәлгәч, ул кинәт аптыранып китте.* Ш.Камал; 2) Тукталып, тоткарланып калу. *Этә белсәң, төртә белсәң, көтә белсәң, Бер басмадан бер басмага күтәрелсәң, Сиңа килеп төрле-төрле эш терәлсә, Дәрәҗәңне саклый белү – мөһим нәрсә.* Г.Афзал. – *Түбәсен яптым, мич чыгарырга кирпеч табып булмый әле менә. Һич юнәтер хәл юк! – Аңа гына калгач, эш терәлмәс!* Ә.Галиев. **Эш тормау** Тоткарлык булмау. *Шифасы тиярлек булса, акчасыннан эш тормас иде.* Т.Гыйззәт. *Безнең архитекторлардан эш тормас! Нинди материал таба аласыз, шуннан эшлибез.* М.Маликова. **Эш төшү** Берәрсенә гозерең, йомышың булу, үтенеч белән мөрәҗәгать итәргә туры килү. *--- җәй башында Гайнуллинны Казанга, министрлыкка эшкә алдылар. Аның урынына хатын-кызны куйганнар иде, моңарчы эш төшмәгәч, онытылып киткән.* М.Маликова. *Эш төшеп Назарбәккә баруым әле ---.* Р.Мирхәйдәров. **Эш тыгыз** Мәшәкать, шөгыль күп. *Эш тыгыз иде: чөгендер чәчүлегендә булдым, солярка артыннан йөрдем...* Р.Камал. *Медпунктта һәр көндәгечә эш тыгыз булса да, Миңнур ахирәтенең: «Серем бар», – дигән сүзләре турында еш кына уйланды.* Ә.Салах. **Эш тыгызга терәлү** Хәлләр начарлану, тормыш кыенлашу. *Өйнең бер бүлемендә аның хуҗасы – Хаҗиның тол сеңелесе Гыйззениса карчык үзе тора, икенче бүлемен, Хаҗиның эше тыгызга терәлгәч, аңар арттырган иде.* Ш.Камал. **Эш узган, туй тузган** «Эш узгач үкенүдән файда юк» дигән мәгънәдә кулланыла. **Эш узу** Абайламый, белми, чара күрә алмый калып, хәл инде төзәтә алмаслык төс алу; соң булу. *«Эх, юкка ычкындырдым!» – дип уйлады ул, кирәкмәгән юмартлык күрсәтүе өчен үз-үзен шелтәләп. Ләкин инде эш узган иде, никадәр үкенсәң дә, терсәкне тешләп булмаячак иде.*

Н.Фәттах. *Карина --- әле һаман үксиүкси елый иде. Үзенең бик зур хатасын сизә, йөрәге сызлый, ләкин эш узган.* М.Хәбибуллин. **Эш чуалу** Мәсьәлә катлаулану, эшләрнең гадәти барышы, тәртибе бозылу, хәл авырлашу. *Туктале, Аланча да, Нурлы бикә дә түгел, аллалар чуалтты микән соң бу эшне? Кем генә булмасын, чуалды эш, чуалттылар.* Н.Фәттах. *Тыны-көне бетеп, Смирнов килеп җитте. Ләкин идарәнең зур ишеге өстенә эленгән сәгать буенча тагын ун минут көтәргә кирәк иде әле. Маллар нишли икән анда, бөтен эш чуалды, шайтан, дип сукранып куйды хуҗа.* М.Әмирханов. **Эш юктан эш булу** *к.* **эш юктан эш табу**. *Эш юктан эш булсын дигәндәй, бу егет мине ауга – бытбылдык атарга чыгарга үгетли башлады.* С.Сабиров. *--- бозау хәтле эт --- чылбырын өзәрдәй булып өрепме-өрә, өстемә ыргылыпмыыргыла. Эш юктан эш булды моңа.* Р.Габделхакова. **Эш юктан эш табу** 1) Әллә ни ихтыяҗ булмаган берәр эшкә керешеп, үзенә яки башкаларга проблема китереп чыгару, кирәкмәгән борчу тудыру; 2) Берәр нәрсәгә сылтау эзләү. *Эш юктан эш тапкан булып, тыкрык башында йөрде, Наилә янына кайтып керәсе килми иде аның.* А.Гыйләҗев. *Шулай истәлекләргә бирелеп утыруым эш юктан эш табып вакыт үткәрү өчен генә түгел.* Л.Ихсанова. **Эш ясау** Мәшәкать, борчу тудыру. *– Минә күпме эш ясадыгыз бит сез миңа, хәзер инде көннең көнендә авыру янына килеп йөрергә кирәк булачак, – диде Евгений Михайлович.* М.Маликова. *Почтага эш ясадык инде. Берара ду китереп хат алыштык.* Ю.Сафиуллин

**ЭШАФОТ** *и. фр.* 1) Үлем җәзасын гамәлгә ашыру өчен ясалган махсус күперчек. *Эшафотның ике метрдан артык биеклектәге нигезе брезент белән капланган.* Ш.Мостафин. *Күпмедер вакыт узгач, эшафотка өч җәллад менеп басты.* З.Мәхмүди

2) *күч.* Үлем. *Ихтыяр, эшафотка барган тоткын кебек, аякларын теләмичә генә өстери-өстери дүртенче катка менеп, кыңгырау төймәсенә басты.* Р.Вәлиев

◊ **Эшафотка күтәрелү** 1) Үлемгә хөкем ителү, үтерелү; 2) Үзен корбан итү. *Нинди карар кылса да, ул әүвәле үз муенына элмәк кия. Патша кебек, тәхеткә менәргә ризалыгын биргән минутыннан башлап, муенына балта чабасы түмәренә башын куя, эшафотка күтәрелү өчен беренче адымын ясый.* Ф.Яхин. **Эшафотка менү** *к.* **эшафотка күтәрелү**

**Э́Ш БАШКАРУЧЫ** *и.* Канцелярия эшләрен алып баручы хезмәткәр. *Мин район халык судына эш башкаручы булып эшкә кердем ---.* Р.Зарипов

**ЭШЕЛОН** *и. фр. хәрби* 1) Гаскәри берләшмәнең сугышның аерым максатларына, аерым урынга карата сугышчан урнашу тәртибе. *Гаскәрнең баш эшелоны*

2) Гаскәрне зур араларга күчерү вакытында төзелгән, бер транспорт чарасында барган вакытлы хәрби берләшмә

3) Махсус йөк яки кешеләр төяп бара торган тимерьюл составы, поезд. *--- машиналар, станоклар, эшче халык төялгән озын-озын эшелоннарны чиратсыз тылга озаткан вакытлар инде үткән иде.* З.Зәйнуллин. *Ә эшелон ул, күпләребез белгәнчә, дистәләрчә вагоннар таккан поезд, ягъни бик озын состав.* Ф.Баттал

**ЭШЕРГЕЧ** *и.* Ачыла-ябыла торган нәрсәләргә бик буларак аркылы салынган, шудырып йөртелә торган тимер пластинка яки таяк. *Кыз исә түр як бүлмәгә ташланды һәм ишек эшергечен этәреп куйды.* М.Хәбибуллин. *Капка ак буяу белән буялган, эшергеч белән бикләп куелган.* Р.Вәлиев

**ЭШЕРЕЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **эшерү**. *Хәзер дала юк: бөтен тараф казылган, чокылган, тишелгән, актарылган, сыдырылган, эшерелгән, өелгән...* А.Гыйләҗев

2) *сөйл.* Төрле авырлыклар, мәшәкатьләр күрү, төрле кыенлыклар кичерү; азаплану, интегү. *Ветеран кызып китте: «Синең миңа «юк» дип әйтергә хакың юк, колхозны менә без төзедек», – диде. --- Яшь рәис: «Сез ул чакта төземәсәгез, бүген мин монда эшерелмәс идем», – диде.* Т.Миңнуллин. *Вахтёрлар, шахтёрлар белән эшләве кыен, шулар белән эшереләм. Элек театрда беренче кеше актёр булган, хәзер вахтёр белән шахтёр.* Р.Батулла

**ЭШЕРМӘ** *и.* 1) *к.* **эшергеч**. *Өйалды ишеге эшермәсен салмак-тыныч кына тартты Ихсан.* М.Хуҗин. *Мөнирҗан бакча яктагы тәрәзәнең эшермәсен ачты.* Н.Әхмәдиев

2) Мичнең шудырып ачыла һәм ябыла торган юллык капкачы, юшкә. *Әнисе мичнең төннек тишеге эшермәсен ябып куйды да сүзен ашыкмый гына дәвам итте ---.* Р.Мирхәйдәров

**ЭШЕРТҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **эшерү**. *МТСның директоры --- Асадуллин: «Мин сине эшеңнән алам» – диде. Шуннан мин: «Алып кына кара, Камалиев абыйга әйтеп эшертермен», – дидем.* Р.Батулла

2) *гади с. к.* **эшерү**

**ЭШЕРҮ** *ф. гади с.* 1) Нәрсәне дә булса, этеп, берәр якка шудыру, күчерү, күчереп кую, бер читкә этәрү. *Нәҗип --- аягын салганда, туфлиләренең җимерек борыннарын, сүтелгән җепләрен абайлап, күз күрмәс төшкәрәк – эчкә эшерде.* А.Гыйләҗев. *Вәли, башындагы кепкасын артка эшереп, пеләшен ялтыратты.* Н.Хәсәнов

2) Эшергеч белән бикләү өчен, аны шудырып кую. *Эшергечне эшерү*

3) *күч.* Куу, тузгыту, пыранлату. *Югыйсә бит иртәгә эш көне, бәйрәм итми калуың да бар. Әле бүген белдем: мине «Совет әдәбияты» редакция коллегиясеннән эшереп чыгарганнар икән.* Г.Бәширов

4) *күч.* Кирәген бирү, ачулану, тиргәү. *Ичмасам, миңа үч итеп, идарәгә сайлап куялар, утырыш саен аягүрә басып: «Элек болай иде, элек тегеләй иде», – дип, мозгамны эшерә инде.* К.Кәримов

**Эшерә башлау** Эшерергә тотыну. *Алтынбай --- кулына сәнәген тотты да: – Икенче кибән менә шунда булыр, – дип, күбәләрне уйнатып, шаяртып, шул урынга эшерә башлады.* Г.Ибраһимов. *Сәвия, ашыгып-кабаланып, алдындагы комны эшерә башлады.* Г.Гыйльманов

**Эшереп җибәрү** Кинәт, кискен рәвештә эшерү. *Аннары --- башын кысып торган ул картузны салып, нindидер җирәнү хисе катнаш бер хәрәкәт белән, эскәмиянең аргы башына таба эшереп җибәрде ---.* Ш.Маннур

**Эшереп карау** Тикшерү-белү максаты белән эшерү. *Түзмим, ---торпышага тараткан ашлыкны, кузгаткан шикелле, тегеләй-болай эшереп карыйм.* З.Мурсиев

**Эшереп кую** Бер мәртәбә эшерү хәрәкәте ясау. *Бәласеннән башаяк дигәндәй, кайнар кофелы чынаягын өстәл уртасынарак эшереп куйды.* Мәйдан

**Эшереп тору** Озак, даими рәвештә яки сөйләү моментында эшерү

**Э́Ш ИТҮ** *ф.* 1) Эш йөртү, гамәл кылу; башкару, үтәү. --- *гомуми агымга, шау-шуга ышанып, гадәттә уйлап эш итүчән, нәзберек каләмле М.Максудның да «Җидегәнчелек» дигән оешманың чыннан да яшәп килүенә инанганлыгына шикләнмәскә мөмкин.* Ф.Галимуллин. *Хәер, үзен күзәтергә*

*алынучылар булса, аларның үзеннән мең кат хәйләкәррәк эш итәсен ул бик яхшы белә иде.* Р.Мирхәйдәров

2) Эшләп бетерү; уңышлы тәмамлау. *Романны эш итеп чыгару*

**ЭШ-ЙОМЫШ** *җый. и.* Берәр нинди йомыш, һәртөрле мәшәкатьләр. *Ирен эшкә --- озату белән, Гөлбану, эш-йомышы булмаса да, әти-әниләре янына йөгерә.* М.Хәсәнов. *Мин, ат җигеп, урман кисүчеләргә су ташыдым җәй буе, вак-төяк эш-йомышларны үтәп йөрдем.* Р.Сабыр

**ЭШКӘРТҮ** *ф.* 1) Булган әйберне тиешле формага китерү, берәр үзлек, сыйфат бирү. *Икенче бүрәнәне, җирдә ятканын, тимерче Саттар эшкәртә.* М.Яһудин. *Ә Килмешәкне авылның шифаханәсенә алып кайтып яткыралар. Тиздән җәрәхәтен эшкәртәләр, ябыштыралар.* К.Җәмит

2) *махс.* Берәр әйбердә кирәкле үзенчәлекләрне, сыйфатларны булдырыр өчен, аңа нәрсә белән дә булса тәэсир итү. *Тире эшкәртү заводы салдырсаң, халыктан чи тире җыеп, шуны заводыңда иләтәсең дә базарга чыгарып сата бирәсең...* М.Галәү. *Генерал салкын кан белән аңлату юлына басты: – Алтынны табу гына җитми, аны эшкәртә белергә дә кирәк, майор.* С.Поварисов

3) Чәчү, утырту өчен әзерләү. *Ә җирне без сабанга үгезләр җигеп сөрәбез, сабан керә алмаган урыннарны исә китмәннәр белән эшкәртәбез.* М.Галәү. *Әти, әни, конкрет эшкә күчик: инде яз җитте, сезнең бакчаны эшкәртәсегез бардыр.* М.Мәһдиев

4) Киләчәктә куллана, файдалана алырлык хәлгә китерү; нәрсәне дә булса билгеле бер тәртипкә салу, кагыйдәнормаларга туры китерү. *Хезмәттәшләребезгә сер түгел: --- чиреклерәк сәяси-публицистик материалларның байтагын басарга әзерләү эшен аңа йөклибез. Дөресен әйткәндә, бәгъзеләрнең андый мәкаләләрне эшкәртергә теше үтми ---.* Р.Фәйзуллин. *Шулай ук язмыш эшедер инде: яшь композитор иҗат эшчәнлеген халык җырларын эшкәртүдән башлый.* Н.Гамбәр

5) Камилрәк, төзегрәк, аһәңлерәк итү, камилләштерү, төгәлләү. --- *театрның дирекциясе, либреттоның телен эшкәртү өчен, Сәетов иптәшкә махсус әдәби редактор беркетергә мәҗбүр булды.* М.Җәлил

6) *күч. сөйл.* Кемне дә булса орышып, тәнкыйтьләп, берәр эшкә мәҗбүр итү. *Бүлек җитәкчесе шактый вакыт эшкәрткәннән соң гына, Альбина эшкә йөри башлады*

7) *күч. гади с.* Кыйнау, тукмау. *Әләк ташып йөргән өчен, Илмираны бераз эшкәртсәң начар булмас иде*

**Эшкәртә бару** Акрынлап, азазлап эшкәртү; булган берсен эзлекле рәвештә эшкәртү. *Икенче мөһим әйбер – басудан кайткан ашлыкны вакытында эшкәртә бару, амбарларга урнаштыру.* Мәдәни җомга. --- *пешкән җимешләрне --- җыеп эшкәртә барырга кирәк.* Кәеф ничек?

**Эшкәртә башлау** Эшкәртергә тотыну. *Алар бу территориядә беренчеләрдән булып, җирне ат ярдәмендә тимер сукалар белән эшкәртә башлыйлар ---.* О.Хисамов. *Татарстанда 1943 елда ук нефть ятмаларын эшкәртә башлаганнар.* Р.Зарипов

**Эшкәртә тору** Һәрвакыт, әледән-әле эшкәртү; булган берен эшкәртү. *Аларга, сабан, үгезләрне вакытында кайтарып җиткереп булмаса дип, чәчүлек җирне китмәннәр белән эшкәртә торырга кушылды.* М.Галәү. *Казларны йолка тордылар, ә Фаина Арысланова аларның эчләрен эшкәртә торды.* Яңарыш

**Эшкәртә төшү** Тагы да ныграк эшкәртү; аз гына эшкәртү

**Эшкәртеп алу** Тиз генә эшкәртү. *Ташучылар йөкләрен бушатып китү белән, Раил Хафизов белән Наиз Фатыйхов яшел массаны тиз генә махсус сыекча белән эшкәртеп алалар.* Кызыл таң

**Эшкәртеп бетерү** Барысын да эшкәртү; тәмам, ахырга кадәр, беткәнче эшкәртү. *Икмәкнең ишелеп уңган елы, элеватор эшкәртеп бетерә алмый, ишегалдында сары гәрәбә тавы – бодай көшеле барлыкка килә.* М.Мәһдиев. *Ул синең болын җир. Аны ничек эшкәртеп бетерим мин, ә?* Ф.Садриев

**Эшкәртеп җиткерү** Кирәгенчә, тиешле дәрәҗәдә эшкәртү. *Сука тигез итеп эшкәртеп җиткерә алмаган участокларда культиватор таккан Степанов Василий һәм Анисимов Мефодий агрегатлары эшли ---.* Р.Зарипов. *Җырларын тәмам эшкәртеп җиткергәнче, композитор һәрвакыт алар белән киңәшә.* Ватаным Татарстан

**Эшкәртеп йөрү** Озак вакыт дәвамында эшкәртү; шушы араларда эшкәртү белән мәшгуль булу. *Сталин турында көфер сүзне беренче тапкыр мин Казахстанда чирәм җирләр эшкәртеп йөргәндә ишеттем.* Татарстан яшьләре

**Эшкәртеп калу** Эшкәртергә өлгерү. *Уңай табигать шартларын оста файдаланып, игенчеләребез --- җирләрне көздән үк эшкәртеп кала алды.* Ватаным Татарстан

**Эшкәртеп карау** Сынау-тикшерү өчен эшкәртү; эшкәртергә омтылу. *Нәҗметдин хаҗи әүвәл чат саен тулып яткан болан тиреләрен җыеп, эшкәртеп карады ---.* В.Имамов. *Бер үк сорттагы бөртекне төрле алымнар кулланып эшкәртеп карыйлар.* Ватаным Татарстан

**Эшкәртеп килү** Күптәннән, әллә кайчаннан бирле даими эшкәртү. --- *авторның гомере буена туктаусыз эшкәртеп килгән «Миллият сүзлеге» исә Адлер Тимергалин иҗатының нәкъ менә икенче юнәлеше, ягъни фәнни эшчәнлегенең бер тармагы булып тора.* Р.Рахмани

**Эшкәртеп кую** Алдан эшкәртү. *Соңгы шигырьләрең дә әйбәт кенә. Бер җидесен эшкәртеп куйдым.* Ф.Яруллин. *Бәрәңгедән алда чүбе баш төртә, бу бәладән котылыйк дип, --- җирне кабат эшкәртеп куябыз.* Шәһри Казан

**Эшкәртеп ташлау** *сөйл.* Тиз генә эшкәртү; кызулык, ялгышлык белән яки аннан-моннан эшкәртү. *Соңыннан белдем: хуҗа кеше алмагачын химикатлар белән катырак эшкәртеп ташлаган икән.* Татарстан яшьләре

**Эшкәртеп тору** Һәрвакыт, гел эшкәртү; хәзер эшкәртү. *Җимеш, яшелчә бакчасы --- теләсә кайда карап, күзәтеп торуны, эшкәртеп торуны таләп итә.* Н.Фәттах. *Санитар таләпләрне үтәп, подъездны тычканнардан, тараканнардан даими эшкәртеп торабыз.* Шәһри Казан

**Эшкәртеп чыгу** Һәрберсен берәмберәм эшкәртү, барысын да эшкәртү. *Еллар үткәч, әлеге истәлекләрне карап-эшкәртеп чыктым.* Р.Мостафин. *Безнең Җәгъфәр Латыйпович, чөгендерне бер кат тулысынча эшкәртеп чыктык, дип, обкомга рапорт бирде инде бүген ---.* М.Маликова

**Эшкәртеп яту** *сөйл. к.* **эшкәртеп тору**. *Ә мине сигез чакрымнан, хатыным, сабый балам белән колхоз чөгендерен эшкәртеп ятканда, сезнең бүлек мөдирегез килеп алды.* Ф.Садриев. *Хәзер мин, Мирзәкәй абый, халык җырларын эшкәртеп ятам.* Л.Лерон

**ЭШКУАР** *и.* 1) Сәүдә, коммерция эшләре белән шөгыльләнүче, бизнесмен. *XX гасырга кергәндә, татар халкы милләт буларак өлгереп җиткән иде, аның иҗтимагый тормыштагы*

*барлык өлкәләрдә дә эш итәрлек зыялылары, булдыклы эшкуарлары --- бар иде.* М.Хәсәнов. *Чын байлыкны әле синең күргәнең юк шул. Аны син түгел, шактый зур табышлы эшкуар булсам да, минем дә күргәнем юк әле.* Г.Галиева

2) *кимс.* Һәрнәрсәдән үзенә табыш, файда эзләп йөрүче; байлык артыннан куучы, малкуар. --- *дәүләтнең болай да саегып калган кесәсеннән миллиард сумнар астыртын сәүдә итүче «эшкуарлар» кулына агыла башлады.* Д.Вәлиев

**ЭШЛӘКИ** *и. диал.* Песнәк. *Озын чыршыга килеп кунып эшләки сайрый башлауны ул февраль ахырында бер зур сөенеч белән каршы ала.* Г.Газиз. *Без бала чагында әни терлекләр карап кереп: «Эшләки килгән, Алла боерса, яз җитә», – дия иде.* Безнең гәҗит

**ЭШЛӘНЕШ** *и.* Нәрсәнең дә булса ясалу, бизәлү, эшкәртелү ысулы; эшкәртелү дәрәҗәсе. *Китап эшләнеше белән бик матур.* З.Зәйнуллин. *Аның бәяләмәсенә караганда, сәнгатьчә эшләнеше ягыннан бик үк югары баскычта тормаган --- пьеса сәхнәдә бөтенләй башка яңгыраш ала.* М.Арсланов

**ЭШЛӘНМӘ** *и.* 1) Җитештерү процессының нәтиҗәсе, ясалган әйбер. *Ул, зур төгәллеккә ирешә алган хәзерлекле эшче, менә күп еллар буена инде бер детальне – шасси штокларын ясый. Бу – зур һәм авыр да эшләнмә, аны станокка да махсус кран белән күтәреп куялар.* Р.Фәизов. --- *бу авылның ике егете бу урында берничә бронза эшләнмә таба.* Р.Садриев

2) Билгеле предприятиедә яки тармакта җитештерелергә тиешле яки җитештерелгән предмет яки предметлар җыелмасы. *Әзер эшләнмәләр цехы*

**ЭШЛӘПӘ** *и. нем.* 1) Кырыйлары читкә чыгып торган баш киеме. *Юань Шикай хәзерләнеп тәмам булды. Киң кырпулы зур эшләпәсен киде.* Г.Камал. *Яныннан узып баручы ак күлмәкле, салам эшләпәле марҗа хатыны аңа сәлам бирде.* Ф.Яхин

2) Озынча сабы, аягы, көпшәсе һ.б.ш. булган берәр нәрсәнең өске, киңәеп килә торган өлеше. *Урман кырыендагы куаклар астыннан аңа кып-кызыл бөрлегәннәр, зур эшләпәсе белән битен каплап үлән астына поскан гөмбәләр карап кала.* Г.Бәширов. *Хатын, әллә эчке бер ярсу, әллә бер дәрт белән, чүкечен кадак эшләпәсенә төшерде ---.* Сөембикә

3) *куч. кимс.* Юньсез, булдыксыз; йомшак, беркатлы кеше. *Әй син, Имрәй, эшләпә, саташтың мәллә, тукта.* Ш.Камал

**ЭШЛӘТӘ** *рәв.* Эшләп, берәр эш башкарып. *Бурычны эшләтә түләү*

**ЭШЛӘ́Ү** *ф.* 1) Нинди дә булса эш башкару, эш белән шөгыльләнү, эшчәнлек күрсәтү. *Килен, син кайта дип, көн-төн бакчада эшләде, аны җимеш агачлары белән тутырды, чәчәкләр үстерде.* Г.Ибраһимов. *Көне буе кырда эшләгәннән соң, Саматны трактор белән ферма маллары өчен болыннан печән тарттырырга җибәрделәр.* А.Фәләх

2) Кайда да булса хезмәт итү, билгеле эш белән дәвамлы шөгыльләнү. *Казан медицина институтын тәмамлагач, башта авыл хастаханәләрендә, аннары Казанда эшләде.* Г.Әпсәләмов. *Әтисе – кандидат, әнисе дә институтта эшли.* А.Тимергалин

3) Берәр хезмәт урынында булу, нинди дә булса вазифа үтәү, кемнең дә булса хезмәтен башкару. *Үзем яслегә эшкә кердем: мөдирә булып эшлим.* А.Алиш. *Сәлимгәрәевич --- урман хуҗалыгында өлкән техник булып эшли икән.* А.Хәлим

4) Нәрсә дә булса ясау, әзерләү, чыгару, җитештерү, продукция бирү. --- *үзен саф, пакь җанлы итеп кабул иткән авыл үзе, --- сырлап-матурлап эшләгән һәр бизәге хәзер аннан йөз чөергән, өметен өзгән, читләшкән кебек.* А.Вергазов. *Без Татарстанга күчкәч, хәрби вәкилләр без эшләгән хәрби продукцияне кабул итми интектерделәр.* Р.Юныс

5) Берәр максат өчен яраклы хәлгә китерү, киләчәктә куллана, файдалана алырлык итү; эшкәртү. *Булган кадәр җирен, чит кеше ярдәменнән башка, семьясы белән үзе эшләп бетерә.* М.Гали. *Май ялларында сөрдереп, бәрәңгесен утыртып, түтәлләр эшләп, язгы эшләрне тәмамлап куярга иде.* Бөгелмә таңнары

6) Хезмәт процессында корал, ярдәмче көч кулланып эш башкару. *Мин сугышка кадәр колхозда ат белән эшләдем – җир сөрдем, иген үстердем.* М.Мәһдиев. *Өй эшен биргәндә, укытучы укучыларның --- сүзлек белән эшләү күнекмәләрен ныгытуны күз алдында тота.* А.Галиуллина

7) Гәүдәнең берәр өлеше хәрәкәт итү; эшне гәүдәнең берәр өлеше башкару. *[Тимернең] бер генә кулы эшләгән.* М.Җәлил. *Тизлек җыйганнан соң, алар аяклары белән эшләүдән туктыйлар, ә велосипед инерция буенча хәрәкәтен дәвам итә.* Мәйдан

8) Хәрәкәттә булу, хәрәкәт итү (механизм, агрегат, җайланма һ.б.ш. тур.). *Ток өзелгәч, мотор эшләүдән туктады.* Н.Хәсәнов. *Трактор эшләп тора-тора да, калтыранып, урыныннан кузгала.* Н.Каштанов

9) Теге яки бу ысул белән, теге яки бу җайланма, материал, чимал һ.б.ш. ярдәмендә хәрәкәткә китерелү. *Карагыз, менә ул минем машинам! --- Нефть белән эшли.* Р.Вәлиев. *Без газ белән эшли торган техника җитештерәбез.* Шәһри Казан

10) Нәрсә дә булса барлыкка китерү, иҗат итү, камилләштерү яки өйрәнү. *Бездә хәзер композитор белән авторның берләшеп, бер проблема өстендә эшләп, бергә оперетта тудыру гадәтен тәҗрибәгә кертергә кирәк.* М.Җәлил. *Сөембикәгә багышланган әсәр өстендә эшләгәндә, Р.Батулла бик катлаулы, шул ук вакытта һичшиксез дөрес юл сайлаган.* Ф.Урманче. *Шәүкәт Таип улы --- диссертация өстендә эшләгән дәвердә генә дә диссертация темасына кагылышы булмаган унлап фәнни хезмәт бастырып чыгара.* Фән һәм тел

11) Оештыру, үткәрү, ясау. *Тотабыз да туй эшлибез.* Г.Коләхмәтов

12) Кемгә дә булса хезмәт күрсәтү, кемнең дә булса файдасына хезмәт итү. *Элек атаң, мескенем, байга эшләп көн күрде ---.* А.Алиш. *Ат җигеп үз файдасына эшләп йөргәнен ачарга кирәк!* Ә.Галиев. *Хәзер хөкүмәткә эшләми, кеше кесәсен калынайта.* В.Гали

13) Кемгә дә карата билгеле гамәл кылу, билгеле мөнәсәбәттә булу; кылу, итү. *Назыйм энем, син кешеләргә изгелек кыл. Инде алар синең яхшылыгыңны аңламаслар дип шикләнсәң дә, барыбер изгелек эшлә үзләренә.* М.Хуҗин. *Әшәкелек эшлим дип, яхшылык эшләп куйганмын икән үзенә, каһәр.* З.Мәхмүди

14) Үз-үзен тоту, билгеле рәвештә гамәл кылу. *Үзе өчен иң якын кешесенең һәлакәтен тизләтә. Шуңа гаепле ул хатын, һәм мин аңа кычкырып дөрес эшләдем. Ул шуңа лаек иде.* А.Вергазов

15) Хезмәт итеп табу, кулга төшерү, алу. *Шахматистлар – башлары, скрипкачылар бармаклары белән эшләгән акчаны нигә миңа башка әгъзам белән эшләмәскә?* А.Хәсәнов. *Сату иткән, дип инде, үз бакчасында үскән яшелчә, җиләк-җимешне сатып, ипилектозлык эшләгән.* Акчарлак

16) Гамәлдә, файдалануда булу; ачык булу. *Теләсә нәрсә әйтегез, ә завод*

*эшли, элеккегә караганда өч тапкырга артык продукция чыгара, ассортимент күзгә күренеп артты.* Р.Вәлиев. *«Без кичке сәгать алтыда киләбез, --- ашарга әзерләгез, без кайтканда ресторан эшләми, зинһар, кулыгыздан килгәнчә ярдәм итегез инде!» – дип ялынасың.* Ә.Шакиров

17) Кем белән дә булса бәйләнеше булу, системалы рәвештә шулар белән эш итү. *Иң мөһиме һәм иң куанычлысы шул: Казан университеты миңа яшь буын – студентлар белән эшләү, аларга булдыра алган кадәр белем-тәрбия бирү мөмкинчелеге тудырды.* Х.Миңнегулов. *Гомер буе ятим балалар белән эшләп тә бу кадәр аптыраганым юк иде...* Г.Гыйльманов

◊ **Эшләмәгән эше юк, кинәндергән төше юк** Бар эшкә дә керешеп, берсен дә юньләп эшләмәүче турында. *[Гыйммран:] Мин колхозчыларга хезмәт күрсәтәм. Кемдә радио-телевизор ватыла, кемдә газ көйсезләнә... [Гаделша:] Эшләмәгән эше юк, кинәндергән төше юк.* Х.Вахит. **Эшләп түгел, кешнәп ярау** Куштанлык, ялагайлык белән ярау. *Кәшшаф элек Президент тирәсендә йөрүчеләрне өнәп бетерми иде, эшләп түгел, кешнәп яраучы ялагайлар, интриганнар, юмагай тел белән куштанлык аркасында югарыга үрмәләгән бушкуыклар, дип саный иде.* М.Әмирханов

**Эшләп алу** Тиз генә, кыска вакыт арасында эшләү. *Быел укырга керергә соңга калдың инде, киләсе ел өчен әзерләнә башларсың... Кышын эшләп алсаң да була, ничә тапкыр мәктәпкә чакыра килделәр бит...* Ф.Бәйрәмова. *Соңгы елларда Ч.Мусин Ижауда басыла торган «Яңарыш» газетасында актив катнаша. Биш ел редакциядә дә эшләп алды.* Казан утлары

**Эшләп ату** *сөйл.* Уйламыйча, кызулык яки ялгышлык белән эшләү; тиз-тиз яки аннан-моннан эшләү. *Бөтенесен шаккатырып, кызыктырып, Берәр әкәмәт эшләп атасы килә!* Ш.Галиев. *Нургаяз --- бераз тынычланмаммы дип, өйләрендә әллә нихәтле эш эшләп атты.* М.Миншин

**Эшләп бетерү** Ахырына кадәр эшләү. *Әле кичә генә балалар ул ояны ашыга-ашыга эшләп бетерделәр, ә бүген инде анда яз кунаклары – сыерчыклар килделәр.* А.Алиш. *Дәрестә кушылганны тиз-тиз генә эшләп бетерәм дә, ни эшләргә белми аптырап, Фатыйма апага: – Апа, мин сез кушканны эшләп бетердем, өстәмә эш бирегез әле миңа, – дим.* Ш.Җиһангирова

**Эшләп җибәрү** Тиз арада яки кинәттән эшләү; эшли башлау. *Ул, кайбер вакыт, ирләр гадәтен онытып, хатыннарча эшләп җибәрә иде.* Г.Ибраһимов. *Мотор яман үкереп эшләп җибәрде.* А.Вергазов

**Эшләп җиткерү** Тиешенчә, кирәгенчә эшләү. *Башы да эшләп җиткерми бит аның шундый чакта: өйгә сугылып, ау чаңгысын элеп кенә килергә булган да бит.* Р.Мөхәммәдиев. *Ильминскийлар эшләп җиткерә алмаганны эшләп бетерү була инде бу.* Р.Юныс

**Эшләп йөрү** Шактый вакыт эшләү. *Айлар, еллар буе сүз тыңлап, бер карышусыз эшләп йөргән егеткә кем базып сүз әйтә алыр?!* А.Гыйләҗев. *Әхәт дустым --- ут чыгарып эшләп йөри.* А.Хәсәнов

**Эшләп калу** Эшләргә өлгерү. --- *бу эшне җир юеш вакытта, ашлама җиргә күп дигәндә ике-өч көн эчендә сеңеп бетәрлек чакта эшләп калырга кирәк.* В.Нуруллин. *Яшь чакта эшләп кал. Әллә зур эшләр башкарырсың әле, күренеп тора.* М.Маликова

**Эшләп карау** Сынау өчен эшләү. *Төзелештә төрлесен эшләп карадым, авыр вакытлары да, күңелле чаклары да җитәрлек булды.* Г.Шәйхи. *– Бетермә, әнисе, үзеңне. Һәркем үз ялгышы аркылы дөреслеккә килә. Берәр ел заводта эшләп карасын, күз күрер тагын, – диде.* Гөлшәһидә

**Эшләп килү** Күптәннән, элек-электән эшләү; эзлекле рәвештә эшләү. *Т.Миңнуллин балалар өчен драма әсәрләре язу өлкәсендә дә уңышлы эшләп килә.* А.Әхмәдуллин. *Сугыш елларыннан ук эшләп килгән ферма мөдире – Гөлбагар исемле, инде олыгаеп барган, бик үзсүзле бер хатын бар иде.* В.Нуруллин

**Эшләп китү** *к.* **эшли башлау**. *Таһир --- Түбән Камада эшкә урнашты, әйбәт кенә эшләп китте.* Г.Гыйльманов. *Аккумуляторы яңадырмы, суынып майлары куерса да, двигатель тиз кабынды, --- күңелле гөрелте белән эшләп китте...* К.Кәримов

**Эшләп кую** Алдан эшләү; бик тиз эшләп бетерү. *Өйдә эшләргә биреп җибәргән мәсьәләләрне генә түгел, киләсе дәрестә эшләргә тиешлеләрен дә эшләп куям.* В.Нуруллин. *Җебеп торганны бер дә яратмый, ни кушсаң, шуны ялт итеп эшләп куя, әткәсенең кул арасына керә башлавына Мостафаның үзенә караганда ныграк та сөенә бугай әле.* Ф.Сафин

**Эшләп ташлау** *сөйл. к.* **эшләп ату**. *Мәхәббәтнең күзе сукыр, диләр, я берәр ахмаклык эшләп ташларсың.* Н.Әхмәдиев. *Бер-бер хата эшләп ташламагаем дип, үземне башлап сүз катарга авыз ачудан тыеп утырам.* А.Хәсәнов

**Эшләп тору** Гел, бертуктаусыз эшләү; сөйләү моментында эшләү. *Бертуктамый эшләп торырга адәм машина түгел ул.* А.Алиш. *Хәзер ул вакыт-вакыт эшләп торган җиреннән туктап кала да уйга чумган кебек була иде.* А.Тимергалин

**Эшләп утыру** *сөйл. к.* **эшләп тору**. *Бүлмәнең түрендә аклы-каралы телевизор эшләп утыра икән.* М.Маликова

**Эшләп чыгу** Барысын да, баштан ахыргача эшләү. *Шулай итеп, бабай-әби йортында кияү йола кушканча эшләргә тиеш кара эшләрнең барысын да эшләп чыкты.* Н.Фәттах. *Әйбәт итеп эшләп чыксагыз, сез бизәгән базар авылыбызның үзәк урынына, барыбызның да күркенә әйләнәчәк...* А.Вергазов

**Эшләп яту** *сөйл. к.* **эшләп тору**. *Болар, дим, үзләре бик тырышлар, дим. Көн дими, төн дими, җәй, кыш дими, туктаусыз эшләп яталар.* Г.Ибраһимов. *Күпме чакырды бит аны дусты, әнә гөрләп эшләп ята хәзер.* Г.Галиева

**Эшли бару** Эзлекле рәвештә, рәттән барысын да эшләү. *Һәр әйткәнне җиренә җиткереп эшли бара торган укытучылар югалып калды ---.* Кызыл таң

**Эшли башлау** Эшләргә тотыну. *Укмаста бәйрәмгә үзләренең электр станциясе эшли башлаячак, дип сөйләгәннәр иде ---.* В.Нуруллин. *Марат алар авылында эшли башлаган елны да көз шулай җылы, матур килгән иде.* А.Хәйретдинова

**Эшли бирү** Бернәрсәгә карамастан эшләвен дәвам итү. *Галимнең куллары күшекте, ләкин ул, авызына тулган тозлы суны төкерә-төкерә, һаман эшли бирде.* Г.Әпсәләмов. *Атлар, аратирә пошкыргалап алып, үз эшләрен күндәм генә эшли бирә – чакрым артлы чакрым артта кала.* З.Мурсиев

**Эшли тору** Башка эш-гамәл барышында эшләү; һаман эшләү. *Ә ул: – Качма миннән, кызыкай, мин барыбер синең тәмле җимешеңне ашаудан туктамаячакмын, – диде һәм, аулаграк урында очраткан саен, этлеген эшли торды.* Ф.Яруллин

**Эшли төшү** Тагын бераз эшләү. *Кайбер формулаларны тагын эшли төшәргә кирәк.* Һ.Такташ

**ЭШЛЕКЛЕ** *с.* **1.** 1) Гамәли әһәмияткә ия булган, мәсьәләнең практик чишелешенә, асылына кагылышлы. *Капиталь ремонт турында сүз барганда, барысы да акыллы, принципиаль һәм эшлекле чыгышлар ясадылар ---.* Г.Әпсәләмов. *Очрашулар вакытында театрларыбызның бүгенге хәле һәм аны яхшырту турында эшлекле сөйләшүләр булды.* Ю.Сафиуллин. *Дәүләт Советының әле узган елның май аенда ук чыгарылган бер карарында бик эшлекле тәкъдимнәр бар иде.* Р.Миңнуллин

2) Белдекле, эштә тәҗрибәле. *Миңа тагын этием әйткән була, авыл егетләре эчкерсез була, эшлекле була, ди.* М.Мәһдиев. *--- яңа дәвер кешесе нәкъ менә Фәнил кебек булырга тиештер: акыллы, эшлекле, техниканы яхшы белүче.* Р.Габделхакова

3) Күңел биреп, бөтен көчен һәм сәләтен җигеп эшләмичә, тырышкан булып кыланган. *Балкыш --- узып барышлый гына: «Культура бүлегеннән ашыгыч йомыш белән җибәрделәр», – дип мыгырдап, эшлекле адымнар белән эчкә узды.* М.Маликова

**2.** *и. мәгъ. тарт. форм.* Иҗтимагый эшчәнлекнең берәр өлкәсендә үзен күрсәткән кеше. *Теге чакта астыртын елмаеп, --- аны озатып калган көнчеләрнең күбесе тымызык күлдәге кортлар кебек үрчегәннәр иде: берәүләр профессор, доцент булып беткән, --- җылы урыннарга хуҗа булган. Кая карама – атказанган фән эшлеклесе, лауреат та дипломант.* А.Гыйләҗев. *– Моның авторы, – диде ул, – безнең арада утыра: безнең җәмгыятьнең 1942 елдан бирле актив эшлеклесе, күренекле язучы, скульптор, художник Мапалагама Випуласара.* М.Мәһдиев

**ЭШЛЕКЛЕЛӘНҮ** *ф.* Эшлеклелек күрсәтү; эшлеклегә әйләнү. *Маклерлар мәш килә, бик эшлеклеләнеп, атның тешен кар[ыйлар].* М.Галәү. *Беренче тапкыр кызкай, --- миңа теге кирәк, бу кирәк, дип эшлеклеләнеп складка алып кергәндә, үземне эрерәк тотарга тырышкан идем.* Л.Таналин

**Эшлеклеләнә бару** Торган саен ныграк эшлеклеләнү

**Эшлеклеләнеп китү** Билгеле вакыттан башлап сизелерлек эшлеклеләнү. *Эчүдән туктагач бик эшлеклеләнеп китте ул.* Х.Камалов. *Озак та үтми, Кәримовның үзе белән дә нидер булды, ул боегып калды, аннары берара бик тә эшлеклеләнеп китте.* Ф.Яхин

**ЭШЛЕКЛЕЛЕК** *и.* Эшлекле **1.** (*2 мәгъ.*) булу сыйфаты. *Кыска бишмәте өстенә ак киндер алъяпкыч япкан --- бу крестьянның эче тулы яхшылык: сабыр холык, ятим балага игътибар, эшлеклелек, хатын сүзенә артык каршы килмичә генә, «ир – баш, хатын – муен» мәкален тормышта раслаучы бер ир.* М.Мәһдиев. *Аларның икесенә дә кыюлык һәм эшлеклелек хас, икесе дә төрле каршылыкларны җиңеп, авылның тормыш хәлен яхшырту өчен тырышалар.* М.Вәлиев

**ЭШЛЕКСЕЗ** *с.* Эш рәте белмәгән, кулыннан эш килмәгән, юньсез, булдыксыз. *Закир исә үзе игътибарсыз, эшлексез бер нәрсә булганга, аның йорты ташландык йортлар кебек күренә иде.* Г.Ибраһимов. *Акыллыдан – акыллы, эшлексездән эшлексез туса, бу дөньяда тереклек әллә кайчан туктаган булыр иде инде.* М.Мәһдиев

**ЭШЛЕКСЕЗЛЕК** *и.* Эшлексез булу үзлеге. *Булдыксызлык – чикләнгәнлек. Эшлексезлек – гадәт. Булдыксызны эшлексезлектә гаепләүдә һәм эшлексезне фидакарьлеккә өндәүдә мәгънә юк.* М.Мәһдиев. *Ул иптәш үзенең эшлексезлеген аклауда шулкадәр эшлекле ки, акылына, фантазиясенә, логикасына хәйраннар калып торасың.* Ш.Галиев

**ЭШЛИЯ** *и. рус* 1) Ат дирбиясенең ике башы камытка беркетелгән каештан гыйбарәт, атның янтыкларыннан, койрык астыннан үтеп, туктаганда яки таудан төшкәндә арбаның, йөкнең авырлыгын тигез төшерер өчен хезмәт итә торган бер предметы. *Атларны бик көязләп җиккәннәр: ялларына ал, кызыл тасмалар үрелгән, калын кара дугада куш кыңгырау, тәңкәле йөгән, тәңкәле эшлия, эшлиянең каеш чуклары ике яктан асылынып тора.* Ә.Еники. *Мәзәк хәл инде: якынрак килгән саен, эшлия затлырак булып күренде. Иһи, бигрәк матур икән ләбаса моның каешлары!* К.Миңлебаев

2) Камытсыз җиккәндә камытны алмаштыра торган киң каеш

**ЭШМӘКӘР** *и.* 1) Эшчән, уңган кеше. *Эшмәкәрне мал басар, эшлексезне йокы басар.* Әйтем

2) Эшмәкәрлек белән шөгыльләнүче, кәсәбәче. *1868 елда заводны күренекле инженер һәм эшмәкәр Н.И.Путилов сатып ала.* Г.Ибраһимов. *Ничек инде мин үземнең, фирмамның бик күп серләрен белгән һәм ун елга якын үзем үстергән кешене ансат кына икенче эшмәкәргә тоттырып җибәрим ди, ә?!* Г.Галиева

**ЭШМӘКӘРЛЕК** *и.* Җитештерү һәм сату, хезмәт күрсәтү һ.б.ш.дан системалы рәвештә табыш алуга юнәлгән эшчәнлек, кәсәбәчелек. *Ул елларда эшмәкәрлек модага кереп киткән иде, кем гәзит-журнал чыгара, кем – китап, дигәндәй, Рафис та, каян башына килгәндер, «Әдәби җомга» исемле гәзит чыгара башлады.* Р.Миңнуллин

**ЭШСЕЗ** *с.* **1.** 1) Даими эш урыны һәм эш хакы булмаган. *Сингапурда рәсми рәвештә исәпкә алынган кырык мең эшсез кеше бар ---.* Р.Мостафин. *Хезмәт биржасына барып, эшсез кеше дәрәҗәсендә регистрацияләнергә булдым.* М.Сәлимов

2) Эшләми, тик йөри торган; эшкә ихлассыз, иренә торган, ялкау. *Эшле кеше эш арттырыр, эшсез кеше эш калдырыр.* Мәкаль. *Ә без, эше барның ашы бар, дибез. Гомумән, бәндә туганыннан алып үлгән көненә кадәр эшләргә тиеш. Чөнки эшсез кеше – кирәксез кеше.* З.Мурсиев

**2.** *и. мәгъ.* 1) Даими эш урыны һәм эш хакы булмаган кеше. *Пенсионерларга пенсия түләргә, эшсезләргә пособие бирергә, картлар йортларын һәм больницаларны тотарга – барысына акча кирәк.* Ф.Яруллин. *Баюның иң туры юлы – бюджет акчасына оешкан берәр фондны кулга төшерү: әйтик, белем фонды, иҗтимагый страховка фонды, эшсезләр белән шөгыльләнү фонды...* Т.Галиуллин

2) Иренчәк, эшкә ихласы булмаган, ялкау кеше. *[Элек] татар йортларында музыка-фәлән дигән шикелле нәрсәләр белән шөгыльләнү дә, иң кимендә, эшсезләр эше хисаплана.* Ф.Әмирхан. *Аның өчен көнбагыш ярып, ишек төбендәге эшсезләр белән гайбәт сатып утыру күпкә рәхәтрәк иде.* Э.Шәрифуллина

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Даими эштән мәхрүм, эше булмаган килеш. *Илне хәерчелеккә батырдылар, миллионнарны эшсез калдырдылар, бер телем икмәкләрен тартып алдылар.* А.Алиш

2) Эшкә йөрмичә, даими эш эшләмичә. *Һәм шунда Русия армиясеннән демобилизацияләнеп, бөтен ил буена эшсез яткан офицерларны яңа төзелеп маташкан Кызыл Армиягә мобилизация ясап җыярга тәкъдим итә.* З.Зәйнуллин

3) Берни эшләмичә, тик; ялкауланып. *Юк, ди, мин эшсез тора алмыйм, мин көн саен нидер эшләргә тиешмен, ди.* Г.Әпсәләмов. *Бер минут та*

*эшсез торырга өйрәнмәгән хатын, үзенә урын таба алмыйча, рәшәткәле тәрәзәдән тышкы дөньяны күзәтте.* Р.Хәбибуллина

**ЭШСЕЗЛӘНҮ** *ф.* 1) Эшсезгә әйләнү, эшләми башлау, эшләүдән туктау. *Була кайчак: эч эзләнә. Баш шәрәфең эшсезләнә. Гомерлек дип уйлап йөргән Бөек Көчең көчсезләнә.* Р.Фәйзуллин

2) Ялкаулану

**ЭШСЕЗЛЕК** *и.* 1) Хезмәткә сәләтле кешеләрнең билгеле бер өлеше халык хуҗалыгында үзенең белем дәрәҗәсенә, хезмәт күнегүенә яраклы эш таба алмаудан гыйбарәт социаль-икътисади күренеш. *Дәүләт органнары каршында шулай ук эшсезлекне бетерү дә төп бурычларның берсе булып тора.* М.Мәһдиев. *Дөнья финанс кризисы сәбәпле, халыкның тормышы авырлаша баруы, --- эшсезлекнең артуы, әлбәттә, Русия җитәкчелегенә файдага түгел.* Г.Галәметдин

2) Эшләмичә тик йөрү, тик яту; ялкаулык. *Кеше өчен зур җәза – ялгыз калу белән эшсезлек бит.* Ф.Яруллин. *Миндә дә бу арада ялдан, эшсезлектән туюга охшаган нәрсә сизелә башлады.* М.Вәлиев

**ЭШСӨЯР** *с.* **1.** Уңган, эш яратучан. *Әйе, бездә сәләтле, хәтта талантлы, эшсөяр каләм ияләре аз түгел.* Р.Вәлиев. *Аннары алар буяучы-сылаучы эшсөяр кызлар янына сугылдылар.* Р.Кәрами

**2.** *и. мәгъ.* Эшчән кеше. *Шәле халкы – олысы-кечесе, сәнәк белән казып, көн саен 18 әр гектар бәрәңге алып барды. Аларга һәр көнне акча түләдек. Мондый эшсөярләргә акча жәл түгел.* Г.Ахунов. *Тарих, «татар бар җирдә хәтәр бар» дип, татар халкының кискен, дуамалрак, көчле холкына гына ишарә итмәгән, ә бәлки аның эшсөярлеген, туган җирен яратуын да --- билгеләгән.* А.Гыйләҗев

**ЭШТЕРЕНҮ** *ф. кимс.* Болганыптулганып йөрү, чуалып йөрү. *«Ә син кайт өеңә, бар, бар, йөрмә». Ләкин Әскәрев кайтмады. Коридорның әле бер, әле икенче почмагында эштеренеп йөрде.* М.Мәһдиев

**ЭШТИ** *и. рус сөйл.* 1) Щи. *Югыйсә ашаганнары юклы-барлы ризык түгел: шулпалары да төрле-төрле (әчегән кәбестә эштие сирәк бирелә), икенчегә итле токмач, ботка яки балык белән бәрәңге ---.* Р.Кәрами

2) *диал.* Гомумән шулпалы аш. *Тегеегет беткәнче явыз булып чыкты, кибет янында тагын беркөнне әйтә салды: – Нихәл, суынган эшти эчеңә килешәме?* М.Мәһдиев. *Ул көнне безне борчак эштие белән сыйладылар.* Р.Батулла

◊ **Эштие суыну** Бирешү, рәте китү. *– Эштиең суынса да, күзең комсыз икән, – диде.* Н.Гыйматдинова

**ЭШ ХАКЫ** *и.* Башкарылган эш күләме яки эшләгән вакыт өчен башкаручыга, хезмәткәргә түләнә торган акча, хезмәт хакы. *Кыш көне конторада утырдым, тәгаенләгән эш хакы юк иде, үзем теләгәнчә, аена 50 сум алып яшәдем.* М.Мәһдиев

**ЭШЧӘН** *с.* **1.** Эш яратучан, тырыш, уңган. *Вәзыйх кебек грамоталы, эшчән, булдыклы кешенең ерактарак булуы хәерле.* Ф.Садриев. *--- аның арыган, эшчән куллары, гәүдә тотышы, утыруы --- карт крестьянның авыр, җитешсез тормыш кичерүен күрсәтә.* И.Илялова

**2.** *и. мәгъ.* Эшче, хезмәт иясе. *Богатырёв җитәкчелек эшендә дә сәхнә эшчәннәренә иң беренче чиратта нәрсә кирәклеген аңлый.* Д.Гыймранова. *Ул чакта ирешкән уңышлар өчен бирелгән рәхмәт хатлары, мактау кәгазьләре, гади эшчәннәргә, җитәкчеләргә бирелгән бүләкләр бихисап.* Ә.Исхаков

**ЭШЧӘНЛЕК** *и.* 1) Эшчән булу сыйфаты; тырышлык, уңганлык. *Өй тирәсендә бакча. Һәр төштә пөхтәлек, эшчәнлек сизелеп тора.* Х.Камалов. *--- үз прицепщигына ул нәкъ шул күзлектән – эшчәнлек, булдыклылык күзлегеннән карарга мәҗбүр булды, һәм ул шундук аңа үзенчә бәя дә бирде.* Н.Фәттах

2) Нинди дә булса өлкәдә, тармакта алып барылган, берәр максатка юнәлдерелгән эшләр, гамәлләр. *Легиондагы кораллы күтәрелеш – аларның җинаятьчел эшчәнлегенең бер нәтиҗәсе...* Г.Әпсәләмов. *Г.Ибраһимовның, башка өлкәләрдәге эшчәнлеге шикелле үк, татар совет матбугатын төзү өлкәсендәге эшчәнлеге дә бай һәм күпкырлы.* М.Хәсәнов

3) Нинди дә булса әгъзаларның үз функцияләрен үтәве. *Кабакның йомшагы һәм төшләре --- ашказаны эшчәнлеген яхшырта, эч кибүләрне булдырмый.* Мәйдан

4) Табигый көчләрнең хәрәкәткә килүе, табигать күренешләренең тәэсире. *Донелли, Атлантиданы җир асты уты (вулканнар эшчәнлеге) харап иткән, дип исәпли ---.* А.Тимергалин

**ЭШЧЕ** *и.* **1.** 1) Җитештерүчән хезмәт белән профессиональ шөгыльләнүче кеше. *Күптән түгел генә эшчеләр бистәсендә булган бер хәлне сөйли алам.* А.Нәҗми

2) Урта яки югары һөнәри белеме булмаган, физик көч куеп эшләүче хезмәткәр. *Авиаторлар бер йортта, геологлар – икенче, шартлатучылар, механизатор-бульдозеристлар, ялланып эшләүче гади эшчеләр – һәркайсы үз өйләрендә торалар икән.* А.Хәсәнов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Җитештерүчән, җитештерү өчен хезмәт иткән. *Әйдүк, әйдүк, Мөнирҗан энем. Килеп бик яхшы иткәнсең, безгә кешеләр, эшче көч бик кирәк.* Н.Әхмәдиев. *Бинасын кузгата алмыйм, төзү материаллары да, эшче көчләр дә юк.* М.Маликова

2) Җитештерү өлкәсендә хезмәт иткән; гади катлауга караган. *Элекке вакытта эшче халыктан берәрсе генә булса да дачада торганны күргәнең бар идеме?* Т.Гыйззәт. *Гади эшче халыкның алай мәхәббәт куертып, аерылышып-кавышып йөрергә вакыты бик калмый аның, агай-эне...* В.Нуруллин

3) Кайбер терминологик сүзтезмәләрдә бөҗәк берләшмәләрендәге аерым бер кортның вазифасын белдергән компонент. *Ана корт булмаса, умарта таркала. Аннары умартада, эшче кортлар белән бергә, бала кортлар һәм пенсионер кортлар да бар. Һәрберсенә үз көченә карап эш бүлеп бирелгән.* Ф.Яруллин. *--- бер ояда бер буыннан булган өч төрле корт төркеме яши – ана корт, сорыкортлар һәм эшче кортлар.* Ф.Бәйрәмова

◊ **Эшче кул** *к.* **эш кулы**. *Эшче куллар азаеп калганда, Мирвәли кебек корычтай нык эшчене комбинат җитәкчеләренең дә җибәрәсе килмәде...* А.Гыйләҗев. *Ул чакларда эшче куллар җитмәде микән, әллә башка сәбәпләре булгандырмы, әти үзенә кунних булып килердәй кеше таба алмый интекте.* А.Хәсәнов

**ЭШЧЕ-КРЕСТЬЯН** *җый. и.* Эшчеләр һәм крестьяннар. *255 км лык юлда Төрекмәнстанның геологиясен, ботаникасын, этнография һәм әдәбиятын, эшче-крестьяннар тормышын рәхәтләнеп өйрәнергә тотындык.* Х.Туфан. *Сәяси тоткыннарны һәм большевикләр сәясәтенә каршы көрәшеп төрмәгә утырган эшче-крестьяннарны азат итәргә!* З.Зәйнуллин

**ЭШ ЯЛЫ** *и. к.* **эш хакы**. *Мин кунакка килмәдем, эш ялымны алырга килдем.* Р.Ишморат

# Ю

**ЮА** *и.* 1) *бот.* Амариллисчалар семьялыгыннан тамыр төбеннән чыккан яссы көпшә кыяклы, аштәмләткеч итеп тә файдаланыла торган сарымсак сыман тугай үсемлеге; кыргый суган; *русчасы:* **дикий лук**. *Бу тәмдә барысы да бар иде: --- яланда печән чапканда кара икмәк белән ашалган юа тәме дә, сугышта окоп казыганда сулыш тыны белән авызга кереп тула торган дымлы ком-балчык тәме дә...* Г.Гыйльманов. *Әбисе әйтә иде, түзик, балалар, тау битендә юа, балтырган чыкса, ачка үлмәбез, дип.* З.Кадыйрова

2) *к.* **юалык** (*2 мәгъ.*). *Шулай, Юа җыены белән юанып, майның өч атнасы узып та киткән, ә дүртенче атнада инде Күҗәкә халкы Олы җыенга Пучы авылына юнәлгән.* Л.Җамалетдинов

**ЮАК** *и. иск., диал.* **1.** 1) Ял итеп алу, үз-үзеңне юату, тынычландыру эшләре. *Эш арасында юакка да вакыт табылган*

2) Юаныч, куаныч

**2.** *с. мәгъ.* 1) Эш арасында бүленеп уйнап алына торган, кыска вакытлы. *Элек аулак өйләрдә уйнала торган юак уеннар булган*

2) Күңел күтәрә торган, куаныч биргән

**ЮА́К-ЙОМАК** *җый. и. иск., диал.* Ял итеп алу вакытында уйнала торган һәртөрле уеннар

**ЮАКЛАНУ** *ф. иск., диал.* Эштән бүленеп, кыска вакытлы ял итеп, юанып алу, күңел ачу; шатлану

**ЮАЛЫ** *с.* Юа үсә торган, юасы булган. *Сөн буйларында гына үсә ала торган татлы юалы әрәмәләр мәңгелекнең үзе кебек борынгы һәм сәнгатьнең үзе кебек гүзәл.* Р.Миңнуллин

**ЮАЛЫК** *и.* 1) Юа күп үсә торган урын. *Юалык таптым, егетләр, бире килегез!* Ә.Фәйзи

2) *этн.* Яшьләрнең ашарга яраклы кыргый үсемлекләрне бергәләшеп җыярга чыгуы белән бәйле язгы күмәк бәйрәм. *Нажия апа Борһанова мәгълүматларына караганда, Дәвеш авылы халкы июнь башында Колгына, Коштавыл һәм Кара Борнаш белән бергә Юалык җыенын бәйрәм иткән.* Ф.Гарипова

**ЮАН** *с.* 1) Аркылы кисем үлчәме зур булган, зур диаметрлы (түгәрәк, йомры әйберләр тур.). *Мин белә башлаганнан бирле, безнең өебезгә генә орынып, юан кәүсәле шомырт агачы үсә.* Н.Кәримова

2) Тулы, авыр гәүдәле, зур бәдәнле, тәнендә мае күп булган (кеше тур.). *Хәзер инде ул саргылт чәчле, сипкелле, --- юан бер кызга әйләнгәндер.* М.Галәү. *Дөресен генә әйткәндә, аның --- юан һәм авыр гәүдәсенә, салмак кына хәрәкәтләренә бу кушамат ябышып та тора иде кебек.* Н.Яһудин

3) Күпкән, күбенгән, кабарып торган. *Юан корсаклы начальник һаман ашыкмый, кәгазен кулына тоткан килеш һаман әрле-бирле йөренә – нервыларны суыра.* З.Мурсиев

4) *сөйл.* Калын, бүселеп торган. *Ул култык астына затлы һәм юан күн папка кыстырган күзлекле егеткә өметле карашын төбәде.* Ф.Җамалетдинова

5) *сөйл.* Калын, түбән тембрлы. *Юан, куе, бәрхет тавышлы иде ул [Мохтар Мутин].* Р.Батулла

◊ **Юан башы** Нәрсәнең дә булса иң авыры, иң кыены, күбрәк зыянлы өлеше. *Сәләмә җиләнле Әухәди, гаепнең юан башы үзендә икәнлеген белгәнлектән, утка баскан песи төсле, йөкләр тирәсендә әйләнеп йөрде.* К.Тинчурин. **Юан башын күтәрү** Эшнең авыррагын, мәшәкатьлерәк өлешен үз өстенә алу, башкару. **Юан кесәле** Күп акчалы. *Кесәсе юанрак яшь байларны син безгә алып кил.* Ш.Мөхәммәдев. *Туймас нәфесле, юан кесәле абзыйлар[ның] төпсез кесәсенә акча агып кереп тора.* Безнең гәҗит. **Юан корсак** *эвф.* Зур байлыкка ия кеше. *Элек юан корсак Ләвәнти каршысында бу агайлар, бүрекләрен салып, бил бөгәләр иде. Менә шул ук кешеләр хәзер, бернидән дә курыкмыйча, аның кибетен җимереп керделәр.* Г.Бәширов. **Юанның сузылган, нечкәнең өзелгән чагы** Бик киеренке, кысан, тормышның җае киткән чак, кризис вакыты. *--- ул еллар – юанның сузылган, нечкәнең өзелгән вакыты иде, без җирне ташламадык, дип әйткәнмен икән, бу – авылны ташламадык, дигән сүз.* Татарстан яшьләре

**ЮАНАЙТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **юанаю**. *Әгәр шул камышларны мең тапкыр юанайтсаң һәм мең тапкырлар озынайта алсаң, шушы бамбукка охшашлы үсемлек барлыкка килер иде.* М.Юныс

2) Юан итеп күрсәтү, юанлык өстәү. *Жабо, волан, баска, бөрмә, бөкләм ишеләр белән бик мавыкмагыз: болай да тулы матур төшләрегезне алар юанайтып күрсәтергә сәләтле.* Сөембикә

3) *диал.* Көр итү, симертү. *Табигать биргәнен ахырдан җайлап кире ала: сылу йөзләрне җыерчыклыга әверелдерә, нечкә билләрне юанайта, зөбәрҗәт тешләрне коя, буй-сынны бөкрәйтә, очкын күзләрне сүрәнәйтә.* Г.Хөсәенов

**Юанайта бару** Торган саен ныграк юанайту

**Юанайта төшү** Аз гына юанайту; тагын да ныграк юанайту

**Юанайтып җибәрү** Бераз юанайту; кинәт юанайту

**ЮАНАЮ** *ф.* 1) Юан (*1 мәгъ.*) булып китү, юанга әйләнү. *Ул [җен туе ясап, йөгертә-йөгертә үтеп киткән җил] тузына, кәгазь вә чүпләрне биеккәбиеккә бөтереп күтәрә, әле, еландай нечкәреп, тәмам югарыга ашкына, әле түбәнәеп, бөтенләй юанаеп, җир туздырып кайнаша.* Ф.Яхин

2) Тулылану, симерү, тазару. *Симереп, юанаеп, аякларын көчкә генә атлап йөргән мактанчык түрә һәм аның купшы йорты инде болай да саруны кайната башлаган иде.* М.Галәү. *Ул олыгайган, ләкин Исмәт кебек юанаймаган, апара корсак булмаган, изрәмәгән, нык, бирешергә уйламый әле.* Г.Әпсәләмов

3) *сөйл.* Калынаю, бүселү. *--- шактый юанайган букчаны Әгъләмнең аяк очына җайлап кына куйды.* Л.Лерон

4) *сөйл.* Калынаю, түбән тембрлы булып китү. *[Гудокның] Күп кычкыра торгач, тавышы да юанайган, карлыккан кебек.* М.Гафури

**Юанаеп бару** Акрынлап, аз-азлап юанаю. *Ул чакта кычыткан чыпчыгы иде бит, ә монда – юанаеп барган ханым.* Ш.Рәкыйпов

**Юанаеп бетү** Тәмам, бик нык юанаю. *--- урта бер җирдәге ачыклыкка*

*утыртылган карлыган, крыжовник куаклары да күптән бер-берсенә токашып, юанаеп беткәннәр иде.* Ә.Еники. *Гел итле токмач кына ашаганга, капка баганасыдай юанаеп беттең инде, Биктимер!* И.Гази

**Юанаеп җитү** Билгеле бер чиккә, дәрәҗәгә җитеп юанаю. *Сыер тиресеннән теккән портфельгә ул, Шыплапшыплап, кәгазьләрне гел тутырды. Юанаеп җиткәч, портфель бозауладыҺәм мөгезсез бер бюрократны тудырды...* Ш.Галиев

**Юанаеп калу** Билгеле бер сәбәптән яки вакыт узудан соң юанаю. *Берничә ел эчендә картаеп, юанаеп калган Алмыш хан аягүрә басты.* Н.Фәттах

**Юанаеп килү** Акрынлап, аз-азлап юанаю. *Кыска гына кара сакаллы, кысыграк күзле, бераз юанаеп килгән агайның өс-башы шәрык зыялыларыныкына охшаш, бик затлыдан.* А.Хәсәнов

**Юанаеп китү** Соңгы арада шактый, сизелерлек юанаю; кинәт кенә юанаю. *Соңгы тапкыр күрешкәннән соң, Вафа ничектер юанаеп киткән, корсак үстергән, кызара-бүртә төшкән иде.* М.Галәү

**Юанаеп тору** Юан булып күренү. *Кар сарган ботаклары күпереп, юанаеп торалар.* Р.Кәрами

**Юаная бару** Торган саен ныграк юанаю. *Әмма табиблар күпме дәвалаcалар да, файдасы тимәгән: падишаһаның саен юаная барган.* Р.Вәлиев

**Юаная башлау** Юанаюга таба үзгәрү. *Генерал – юаная башлаган ир уртасы кеше.* Г.Әпсәләмов

**Юаная төшү** Аз гына юанаю; тагын да ныграк юанаю. *Сандра яшьлегендәге кебек үк чибәр, тик бераз юаная төшкән иде.* З.Мәхмүди

**ЮАНДЫРГЫЧ** *с. к.* **юаткыч**. *Дәүли абый гәүдәгә бик таза, нык кына булып, сугыш алдыннан гына Донбасска күмер чабарга китеп барган, юандыргыч хатлары атна саен килеп торган.* Р.Кәрами

**ЮАНДЫРУ** *ф.* 1) *к.* **юату**

2) Тынычландыру, өмет уяту. *Кайгырганда – юандыра, сөенгәндә куандыра торган таныш симфония...* Казан утлары

**ЮАНЛЫГЫ** *бәйл.* Аркылы кисем үлчәмен, диаметрын алдагы сүз белдергән әйбернеке белән чагыштырганда «кебек», «хәтле» мәгънәсен белдерә. *Ихатаң җимерелсә дә, абзар-кураң тузса да, бармак юанлыгы тал коткарды.* Ф.Яруллин. *Нәкъ минем аска гына чыршы ботагының бастырык юанлыгын салгансыз бит, хәчтерүшләр.* А.Хәсәнов

**ЮАНЛЫК** *и.* 1) Йомры, түгәрәк әйбернең аркылы кисем үлчәме зурлыгы, диаметры. *Бәхәскә китсә, [Фәйзелхак] алты метрга киселгән егермешәр сантиметр юанлыктагы бүрәнәләрне прицепка ялгызы төйи.* Ю.Әминов. *– Карагыз әле, бүрәнәләр төрле юанлыкта бит, тротуар тигез булсын өчен, аларны бертигез итәргә кирәк, – диде Мәгалим.* З.Мурсиев

2) Юан булу хәле. *Юанлык һәм тазалыкка кызыкма син, тора-бара, шундый зифа чакларыңны ничек кайтарып алырга икән, дип хыялланырсың әле.* Р.Мөхәммәдиев

**ЮАНТЫК** *с.* Юан һәм кыска буйлы; карсак. *Камыт аяклары белән әвеш-тәвеш килеп урамнан бер юантык карчык барса, ул – Газзәтти.* М.Мәһдиев. *Буйга Галимҗан абый, мөгаен, калкурактыр, ә Ильясов тәбәнәк, юантык гәүдәле, корсагы да ару сизелеп тора.* В.Имамов

**ЮАНУ** *ф.* 1) Елаудан туктау, тынычлану. *Бишектәге бала, хуш авазга юанып, елаудан туктый һәм игътибарын шул авазны тыңлауга юнәлдерә.* Ш.Мәрҗани

2) Кайгы-хәсрәт, борчудан, күңелне ярсытып торган ярадан нинди дә булса шөгыль ярдәмендә арынгандай булу, тынычланырга тырышу. *Шулай сәгатьләр буе күгәрченнәре белән юанып, гәпләшеп утыра иде Хәлимә әби.* Г.Гыйльманов

3) Күңел күтәрелү, кәеф яхшыру, шатлану. *Бу котлауларга мин бер хәтергә алу, авыруның күңеле юансын, дигәннән иптәшләрчә бер эш дип караган идем.* Г.Ибраһимов

4) Нәрсәгә дә булса бирелеп, чынбарлыктагы халәтеннән читкә китү; онытылу, мавыгып китү. *Бар иде, ялгыз калып, җырлап юанган чакларым.* Г.Тукай. *Күнегелгән сәгатендә торып эшкә китә, заводта көне эш белән юанып үтә, ә тулай торакка кайткач, үзен кая куярга да белми җәфалана иде...* З.Мифтахов

5) Нәрсәне дә булса уйлап, шуңа күңел баглап, өметләнеп яшәү. *Мин моңа бераз борчылсам да, кара кайгыга төшмәдем, озакламый авылга кайтам, шунда очрашырбыз әле, дип юандым.* М.Кәбиров

6) Бар булганына канәгатьлек күрсәтеп, риза булып, артыгын теләмичә, ниндидер максатларга омтылмыйча яшәү. *Һәм үз хыялы җимеше булган шул хәбәрләргә юанып, шуларны чынга санап, берьялгызы тик яши бирә.* Р.Мөхәммәдиев. *Ни дип, күрәсен күргән, яшисен яшәгән Чалабайга ияреп, шуңа иш булуына юанып, егет башы белән мәхлук сарыклар артыннан теркелди?* Т.Әйди

7) Бушка вакыт уздыру, вакыт үткәрү. *Ул бит синең белән юанып кына ташламаган, гомерлеккә тормыш юлдашы иткән, туасы баласының анасы итеп сине сайлаган.* З.Кадыйрова. *Чишмәләр салкынында, агачлар күләгәсендә рәхәт тә бит, хатыны юл кырыенда басып торганда, монда артык юанып та булмый.* В.Гали

8) Берәр эшне артык озак эшләү, озакка сузу, мыштырдау. *Юлда озаграк юанып, вакытында бушатырга соңарып, ул чакта Газинурның бер оя кортлары пештеләр.* А.Хәсәнов

**Юанып алу** Кыска вакыт, аз гына юану. *Бала белән юанып алгач, күңеле бераз тынычланып киткәндәй булды, тынгысыз уйлар югалып торды.* Н.Фәттах. --- *фаҗигалы истәлекләрне барлап, үзеңнең исән калуыңа юанып аласың...* М.Галиев

**Юанып йөрү** Озак вакыт дәвамында, хәзерге вакытка кадәр юану. *Моңарчы ирешелгән уңышлар белән мактанып, юанып йөрүдән туктарга вакыт.* Ә.Еники. *Күзен сирпеп бер исәнләшеп китсә, миңа ике-өч көнгә юанып йөрергә шунысы да җитә җитүен.* М.Хуҗин

**Юанып калу** Хәзерге вакытта бар булганына риза булып, канәгатьләнеп юану. --- *[карт] тәмам зәһәрләнгән, нәрсә булса шул, дип бара һәм икелемикеле җавап белән генә юанып калырга һич исәбе күренми иде.* Ф.Хөсни

**Юанып кую** Кинәт кенә, бераз юану. *Ни борчылган булса да, Салиха апа: «Ярый әле өс-башлары сүз әйтерлек түгел, бөтенесе гөл кебек», – дип, бераз юанып куйды.* М.Маликова

**Юанып тору** Әлегә, вакытлыча юану; билгеле вакыт юану. *Ярый әле юанып торырга балам бар, ул да булмаса, монда эчең пошып үләр идең.* Г.Исхакый. *Ачуым да килмәгәе, Ләлә белән йөридер, дип юанып торсам, ул анда ишәк сугарып йөри.* М.Фәйзи

**Юанып утыру** *сөйл. к.* **юанып тору**. *Яшемне санап, юанып утыра*

*торганнардан түгелмен, эшсез бер генә сәгать тә торганым юк.* Р.Баттал

**Юанып яту** *сөйл. к.* **юанып тору**. *Әлбәттә, бакчаны бер җайга салып җибәрсәк, эткәйгә юанып ятарга әйбәт нәрсә булыр иде.* Ф.Яруллин

**ЮАНЧЫК** *и. диал. к.* **юаныч** (*1 мәгъ.*). *Баланың юанчыгы – уенчык.* Әйтем

**ЮАНЫЧ** *и.* **1.** 1) Юандырырлык, тынычландырырлык әйбер, сүз, эш яки хәл, шөгыль. *Үчнең әрнеткеч газабы түзеп булмаслык хәлгә җиткәч, бәк бабасы Акбулатның сүзләреннән юаныч эзли башлады.* М.Юныс. *Аңа, дус-ише, туган-тумачасы булмаган һәм халык арасына чыгып йөри алмаган кешегә, чын мәгънәсендә бер юаныч иде ул телевизор.* В.Нуруллин

2) Күңелне ача, юата, тынычландыра торган зат. *Бу авыр сынауда хатыны Тәскирә аңа зур таяныч, аяк очында бөтерелеп йөргән малае юаныч булды.* Г.Гыйльманов

**2.** *с. мәгъ. к.* **юанычлы**. *Радиодан да юаныч хәбәр ишетелмәде.* Г.Әпсәләмов. *Юаныч сүзләр ялкыны һәм суыклыгы...* Н.Абдулкәримова

**ЮАНЫЧЛЫ** *с.* Юата, күңелне ача, тынычландыра алырлык, юаныч китерә торган. *Арып, җәфаланып беткән кешеләр өчен бу – бүген ишетелгән бердәнбер юанычлы сүз булды.* М.Галәү. *Сугыш вакытында андый сорауларны бирү куркыныч, бервакытта да юанычлы җавап ала алмыйсың.* Т.Нурмөхәммәтов

**ЮА́Н ЭЧӘК** *и.* Имезүче хайваннарның һәм кешенең ашкайнату трактында чыгарып ташланырга тиешле эшкәртелмәгән азык калдыклары җыйнала торган әгъза, азаккы эчәк. *Бөтен эчен ярып, юан эчәккә операция ясадылар.* З.Кадыйрова

**ЮАТКЫЧ** *и.* **1.** 1) Юаныч бирерлек нәрсә. *Бу – тормыш барышын акларга тырышудан туган бер юаткыч иде.* М.Гайнетдинов

2) Кечкенә балаларны юату, тынычландыру, дәртләндерү өчен, сөйләм ритмы белән хәрәкәт ритмын туры китертеп әйтелә торган кыска күләмле шигъри әсәр (мәс., *Йокла, йокла, гөлием, Кая, битең үбием*). *Физик яктан чыныктыру, үстерү өчен, бәбигә төрле күнегүләр (кул-аякларыннан тотып гимнастика ясату, үчтеки итү, тез өстендә биетү, ике куллап, баланың күкрәгеннән аякларына кадәр сыпырып, үс-үс иттерү) ясарга кирәк. Халык әнә шундый күнегүләр эшләткәндә әйтелә торган махсус әсәрләр – юаткычлар иҗат иткән.* Л.Сираева

**2.** *с. мәгъ.* 1) Юата алырлык, юата торган. --- *үз эченә бикләнеп калган картның ничек тә күңелен күтәрәсе, аңа юаткыч сүзләр әйтәсе килә иде.* Ф.Латыйфи

2) *махс.* Күңелне күтәрә, күңелне ача, юата торган; *русчасы:* **утешительный**. *Яңа ел якынлашуын истә тотып, уенның гадел үтүен тикшереп-күзәтеп утырган укучылар арасында юаткыч призлар уйнаттык.* Туган як

**ЮАТУ** *ф.* 1) Елаудан туктату, тынычландыру. *Кечкенә чакта Ибрайның бишеген җилләр тирбәткән, көйсезләнсә – кошлар сайрап юаткан, авырып китсә – урман чәчәкләре үзләренең шифалы суларын эчереп терелткәннәр.* Ф.Яруллин. *Әни кеше сабыен ничек юатырга белми янында бөтерелә.* Г.Галиев

2) Кайгысы булган, кыенлык кичергән кешене тынычландыру, күңелен күтәрү. *Нәсимнең юатып, аның күңелен күтәрергә тырышып әйткән сүзләре барыбер йөрәгенә барып җитмәде.* Н.Фәттах. *Ләйлә кизү торучы шәфкать туташын чакырып кертте дә, әнисен елмаюлы карашы белән юатып, чыгып китәргә җыенды.* М.Маликова

3) Өметләндерү, ышаныч уяту. *Шундый чаклар була: вакытында Иң кирәкле эшне кылмый калгач, Үземне дә бик еш юатам мин: Булыр әле, булыр!* Р.Миңнуллин. *Моңа кадәр ул үзен, ятим балага да якты кояш бер багар, дип юатып яши иде.* В.Имамов

**Юата башлау** Юатырга тотыну. *Әнисе аны күкрәгенә кысып юата башлады, аның «бай, бай, баю» дигән сүзләре ишетелде.* Г.Әпсәләмов

**Юата төшү** Бераз, берникадәр юату. *Бу сүзләр Хәйретдиннең күңелен азрак юата төшкәндәй иттеләр.* Н.Яһудин

**Юатып алу** Тиз арада, аз гына юату. *– Эше бетсә, менә кайтып җитәр, – дип, үзен үзе юатып алды карт.* Р.Батулла

**Юатып бетерү** Тәмам тынычланганчы юату. *Миләүшәне дә юатып бетерәсем бар.* Кәеф ничек?

**Юатып йөрү** Озак вакытлар дәвамында юату. *«Үкенүдән файда юк – үзем сайлаган язмыш», – дип, күңелен юатып йөрде.* В.Имамов

**Юатып карау** Юатырга омтылу, юатырга тырышу. *Ни кылырга да белмәгән Сәет Габдрахманны әле кочаклыйиркәли юатып карады, әле, аптырап, үзенең колакларын томалады.* В.Имамов

**Юатып килү** Күптәннән, әллә кайчаннан бирле даими юату. *Зәйнәп әби дә: «Кайтыр, Алла бирсә, кайтыр», – дип, аларны юатып килә иде.* Ф.Яруллин

**Юатып тору** Һәрвакыт, гел юату. *Аны, менә язабыз, инде язабыз, дип, гел юатып тордылар, ләкин шулай да язарга ашыкмадылар.* Ә.Еники

**Юатып чыгу** Нинди дә булса вакыт дәвамында, билгеле вакытның башыннан ахырына кадәр юату. *Сабыйны әнисе төн буе юатып чыга.* Казан утлары

**ЮАТУЧЫ** *и.* Юата алырлык, юатырга алынган кеше. *Аны аңлаучы да, күңелен юатучы да булмый.* Ф.Хуҗин

**ЮАЧ** *и. диал.* Зур елгаларның тау ягына каршы болын ягында үскән урманлык; урманлы тугай. *Чипча буйкайлары юач-юач, Юачлары саен сандугач.* Җыр

**ЮАЧА** I *и.* **1.** 1) Вак-вак күмәч яки бавырсак рәвешендәге, майда кайнатып пешереп әзерләнә торган камыр ашы. *Мондый чакларда әнисе иртәдән әзерләнә башлар иде: камырын баса, ипи сала, майда юача, бавырсак чыжлата, токмачын җәеп, киптереп, кисеп куя.* Т.Гарипова

2) Гомумән теләсә нинди туй ризыгы, туй сые. *Кода берлән кодача әзерлиләр зур юача.* Ш.Мөхәммәдев

**2.** *с. мәгъ.* Майда кайнатып пешереп әзерләнә торган. *Менә юача икмәк. Менә кабартма, каймак белән ашарсың.* Р.Ишморат

**ЮАЧА** II *и. к.* **юа**. *Ык буенда юачалар, җиләк-җимешләр генә ашап үскән бик тә чибәр кызым бар минем.* Г.Бәширов. *Юачаларны юып салгач, куна такталары бушар.* Ә.Фәйзи

**ЮАШ** *с.* **1.** 1) Тавыш-гаугага күтәрми, талашмый торган, тыныч холыклы, басынкы, күндәм. *Юаш, басынкы Сәмигулла карт бер читтәрәк тора һәм, бу шау-шуны кузгатуына үкенгән сыман, сакалын тарткалый иде.* А.Гыйләҗев

2) Зәгыйфь реакцияле, сүлпән, мөстәкыйль эш йөртми торган. *Аеруча бу үшән, юаш Сәхапкә карасаң, тормыштан гайрәтең чигәр, билләһи!* Г.Гыйльманов

3) Һөҗүм итми, тешләшми, зыян салмый торган (шундый ихтималы булган җан ияләре тур.). *Акъялның ыжгырып үзе өстенә килүен күргәч, шүрләде, ахрысы, утардагы икенче бер юаш*

*атны җигеп йөрүне кулайрак санады.* В.Имамов

4) Басынкылык, сабырлык, мескенлек сизелеп торган, артык йомшак (кыланыш, тавыш, үз-үзеңне тотыш һ.б. тур.). *Бу акыллы, юаш күзләр Морозовта бүген ни өчендер озаграк тукталдылар кебек.* Г.Әпсәләмов. – *Сергеев чыннан да Рәсәй дошманы шикелле эш иткән бит, – дип, Михляевның юаш тавыш белән сүз кыстырып куюы Пётрга яңа дәрт өстәде.* В.Имамов

5) *күч.* Әкрен, талгын, салмак. *Иртәнге якта кар булып яварга тиешле язгы дым, күңелендәге өмет җылысыннан эреп, юаш яңгырга әверелгән.* К.Кәримов

**2.** *рәв. мәгъ.* Йомшак кына, тынычлык саклап, саклык белән. *Аның кырында очкан озын гәүдәгә юл сабып, юаш елмаеп, Фәридун Фазлыев басып тора иде.* А.Гыйләҗев

**ЮАШАЮ** *ф. диал. к.* **юашлану**. *Җә, Шиһап, хәзер ник болай юашайдыгыз?* М.Гафури. *Буран бераз басылган, куркыныч тавышлар юашайган иде.* Х.Кәрим

**ЮАШЛАНУ** *ф.* 1) Холкында юашлык сыйфатлары барлыкка килү, юашка әйләнү. *Соңгы вакытларда үз-үзенә йомылды Сөмбелә, юашланды, бәхетле үткән кыз чагы матур төш булып кына калды.* М.Хәбибуллин. *Ул елан каршында торган куян кебек юашланган, буйсынган, катып калган…* Г.Закирова

2) *күч.* Басылу, тыну, сүрелү, тукталып, тынычланып калу. *Шуннан соң лампаның ялкыны тилереп биюеннән туктый, юашлана, тигез генә яна башлый.* Г.Әпсәләмов

**Юашлана бару** Акрынлап, аз-азлап юашлану. *Һәр фикер саен туктап, тын алып, янә көр-гайрәтле аваз белән сөйләгәндә, Сафа Гәрәй ханга баласытып караганнарның мәгърур башы иелә, мыскыллы, вәкарь карашлары юашлана барды.* Р.Батулла

**Юашлана башлау** Юашлану билгеләре күренү. *Ул [Миңлебай], инде юашлана башлап: – Алайса Җаекка төшеп су эчеп меник, башларны юып алыйк, – диде.* Н.Яһудин

**Юашлана төшү** Тагы да бераз юашлану. *Картның башта шактый көр чыккан тавышы отыры юашлана төште.* Р.Кәрами

**Юашланып бетү** Тәмам, бик нык юашлану. *Юашланып беткән үшән бүре Карап тора әнә читлектән…* И.Гыйләҗев

**Юашланып калу** Билгеле бер вакыттан, сәбәптән соң юашка әйләнү. *Табигать, котырып-дулап алганнан соң, ничектер хәлсезләнеп, юашланып кала.* Ә.Еники

**Юашланып китү** Кинәт, көтелмәгәнчә юашлану. *Гөлбануга бу алыптай гәүдәле, уйнаган кебек кенә яшәгән кешенең кинәт оялчанланып, юашланып китүе сәер тоелды.* Т.Гарипова

**Юашланып тору** Әле, хәзерге вакытта, күз алдында юашлану. *Анда шулай сукыр көчек кебек юашланып торсаң, сиңа момент тәре кидерәләр.* В.Имамов

**ЮАШЛЫК** *и.* 1) Гауга-низаг күтәрми торган, тыныч холыклылык, басынкылык, күндәмлек. *Матур кара күзләрендә аның юашлык, моңсулык сизелә иде.* Н.Фәттах. *Ислам юашлык, сабырлыкны алга куеп, кыенлыкка күнегеп яшәргә өйрәтә.* Н.Абдулкәримова

2) Сүлпәнлек, җебегәнлек, булдыксызлык. *Болай китүегезне җебегәнлек, юашлык итеп аңларга ярамый.* М.Хуҗин. *Юашлык, үшәнлек, телсезлек, власть кушканны җырлау – интеллигентның мескенлеге, кирәксезлеге.* Н.Шәрифуллин

**ЮБАЛГЫ** *с. диал.* Ялкау, җыйнаксыз һәм шапшак. *Аның ире бик юбалгы, тәртипсез кеше иде, укытучы булса да, аракы эчәргә яратты.* Р.Батулла

**ЮБИЛЕЙ** *и. лат.* Берәр әһәмиятле, истәлекле вакыйганың яки берәр кеше тууының яисә иҗатының түгәрәк санлы еллыгы һәм шуңа багышланган кичә, тантана. --- *аның [Равил Шәрәфинең] Камал театрында үткән юбилей кичәсендә утырырга түгел, басып торырга да урыннар юк иде.* Ф.Мөслимова

**ЮБИЛЯР** *и. рус* Юбилее үткәрелгән вакыйга, шәхес, объект һ.б. *Юбиляр тарафына бик матур теләкләр яңгырады, кызыклы номерлар белән ял иттерделәр, бүләкләр, чәчәкләр дә мулдан иде.* Л.Йосыпова

**ЮБКА** *и. пол.* 1) Гәүдәнең билдән балтырга кадәрге өлешенә киелә торган хатын-кыз киеме, итәк (*2 мәгъ.*). *Аның [Һаҗәрнең] өстендә кара юбка белән чигүле ак кофта.* Г.Әпсәләмов

2) *күч. эвф.* Гомумән хатын-кыз заты; кызлар, итәк (*8 мәгъ.*). *Тәүбә итәм кызлар сөяргә... --- Һәрбер юбка алдында Тиңсез башым юкка ияргә.* Һ.Такташ

**ЮВЕЛИР** I *и. голл.* 1) Затлы металлар һәм җәүһәр-асылташлардан бизәнү әйберләре ясаучы оста, зәркән. *Камчы сабы да сөяктән, аны да ювелир бизәкләгән.* Г.Гомәр

2) Шундый әйберләр сатучы, шул әйберләр белән сату-алу итүче. *Күзгә төртсәң күренмәслек караңгы төндә, таныш түгел шәһәрнең ювелир кибете янында, гасабиланып, милиционерлар йөрнә, имеш.* Р.Мирхәйдәров

3) *күч.* Үз эшен пөхтә, оста итеп башкарырга сәләтле кеше. *Нечкә эш! Аның [резервуарларның] стеналары юка, монда ювелир булырга кирәк!* А.Гыйләҗев

**ЮВЕЛИР** II *с.* 1) Затлы металлар һәм җәүһәр-асылташлардан ясалган. *Шул ук чорда нечкә һәм бай бизәклэрдән торган тукымалар, бизәкле чигү, сырланган савыт-саба, ювелир әйберләр һәм бизәкле сугыш кораллары эшләнә башлый.* К.Гыйззәтов

2) *күч.* Төгәл, оста итеп эшләнгән, башкарылган. *Хикмәт хәтта шигырьләрнең ювелир эшләнешендә дә түгел, хикмәт ул әсәрләрнең – зурмы, кечкенәме – үз заманын объектив чагылдыра алуында, чор рухын бирүендә.* Р.Фәйзуллин

**ЮВЕЛИРЛА́РЧА** *рәв.* Ювелир кебек, нечкәләп, җиренә җиткереп, зур осталык, зәвык белән. *Ул студиягә зур әзерлек белән килә һәм һәр җырны ювелирларча, бөтен нечкәлекләрен җиренә җиткереп башкара ки, әйтерсең лә аның тавышы гына түгел, ә бөтен күзәнәкләре җырлый.* Р.Курамшин

**ЮВЕЛИРЛЫК** *и.* 1) Ювелир (I) осталыгы; ювелир һөнәре, ювелир булу. – *Әллә ювелирлыкка укытырга инде моны [олы малайны], – дип тә уйлап куя иде кайчакта Гамил.* М.Маликова

2) Затлы металлар һәм җәүһәр-асылташлардан бизәнү әйберләре ясау эшчәнлеге. *Болгар чорында ук ювелирлык, агач эшкәртү, итек басу, күн эшкәртү кебек һөнәрләр үсеш алган.* З.Садыйкова

**ЮВЕЛИРЧЫ** *и. ялг. к.* **ювелир** I

**ЮВЕЛИРЧЫЛЫК** *и. ялг. к.* **ювелирлык** (*2 мәгъ.*)

**ЮГАЛТУ** I *ф.* 1) Милкен, үз карамагында булган әйберен саксызлык белән төшереп яки онытып калдыру, җую. *Бу инде үз өе ишегенә ачкычын югалтып, керәлми интеккән бичараны хәтерләтә.* З.Мурсиев

2) Билгесез җирдә аерылып калу, ялгыш ялгызы торып калу. *Әниләрен югалткан каз бәпкәләренең ачырга-*

*ланып аны чакыруы авыл очыннан ук ишетелә иде.* М.Талипов

3) Кемнеңдер кайда да булса тоткарлануы, озаграк күренми торуы сәбәпле, башка берәүнең аны кирәксенә башлавы. *Өйдәгеләр югалткандыр инде безне.* Р.Сәгъди

4) Берәр үзенчәлеген җую, нинди дә булса сыйфаты, сәләте юкка чыгу, бетү. *Инде гарипләнеп, сәламәтлеген югалтып кайткан фронтовикка кулак малае дип бәйләнергә батырчылыклары җитмәде, ахры.* З.Мәхмүди. *Алсинә, аң-хәтерен югалткан кешедәй, кай тарафка юнәлергә дә белми, больница ишеге төбендә бераз таптанып торды.* Р.Габделхакова

5) Азайту, киметү. *Һавага һәр күтәрелгән саен, очучылар гәүдә авырлыгын шактый югалта.* Ф.Хуҗин. *Карчыга никадәр көчле, үткен тырнаклы булмасын, әгәр дә аңар югарыдан китереп канат белән бәрсәләр, һавада тизлекне югалтып, түбәнгә төшеп китәргә мәҗбүр.* К.Рәхим

6) Әрәм итү, тикмәгә сарыф итү. *[Салларны, каекларны] Үзебезгә әмәлләргә туры килсә, күп вакыт югалтачакбыз.* М.Әмирханов

7) Нинди дә булса сәбәп, тоткарлык, кимчелек һ.б. аркасында зыян күрү, зарар алу. *Менә бит ул ничек: өч меңне кесәсенә салып килгән Гафият хаҗи җиңел генә үз тормышын җайлый алган, ә ярлы-ябага, монда килгәч, соңгы тиеннәрен дә югалткан.* М.Галәү

8) Якын, сөекле кеше вафат булу сәбәпле, аннан мәхрүм калу. *Боларын мин соңыннан, инде Азатны югалтканнан соң гына белдем.* А.Тимергалин. *Сигез яшькә җиткәч, аналарын да югалттылар.* М.Әмирханов

9) Яшерү, юкка чыгару, качыру. *Тик бу тирәдән эзне югалтырга кирәк миңа.* З.Зәйнуллин

10) Язу, ялгыштыру, тапмау. *Авыр чиләкләрен күтәреп кайтырлык хәле дә калмады, җитмәсә, гомер бакый йөргән урманында юлны да югалтты.* Р.Рахман. *Төнлә юнәлешне югалту – хәтәр нәрсә, бөтенләй әллә кая килеп чыгуың бар.* Ф.Хуҗин

11) *күч.* Билгеле бер эзлеклелектән, тәртиптән язу, буталу. --- *зиһене сүзләрнең тәртибен югалтып, Гөлшат Фаиковна бөтенләй дә эчсез-тышсыз калды.* Ф.Яхин

12) *күч.* Кулдан ычкындыру, форсатны качыру. *Шушындый йомшак холыклы булуым белән күпме биеклекләргә күтәрелә алмыйча калдым, күпме мөмкинлекләрне югалттым.* Р.Фәизов

**Югалта бару** Торган саен күбрәк югалту. *Үз холкымны һаман югалта барам, кешеләр генә түгел, үзем үземне дә танымыйм.* А.Гыйләҗев

**Югалта башлау** Югалтуга таба бару. *Такташлар мактаган, һичбер нәрсә белән дә тапланмаган Бөек Ана образын югалта башладык бит.* З.Мәхмүди

**Югалта төшү** Тагын да югалту; бераз, берникадәр югалту. *Карт килеп туктады, җетелеген шактый югалта төшкән күзләре белән йөземә текәлде.* Ә.Хәсәнов. *Кадими классик шигъри әсәрләрне мәкам белән башкару сәнгатен хәзерге вакытта югалта төштек сыман.* Г.Макаров

**Югалта язу** Чак кына югалтмый калу; югалтырлык дәрәҗәгә җитү. *Фикри мөстәкыйльлек җәһәтеннән бөтенләй үз йөзен югалта язган вакытлы матбугат бер урында таптанып калды.* М.Госманов. *Сәүбән әнә шул тоемын югалта язды ахры.* Г.Гыйльманов

**Югалтып алу** Кыска вакытка, азга гына югалту. *Шулай да, Гаделне югалтып алган берничә минут эчендә Мирвәлинең күңеленә кара шом кереп өлгергән иде инде.* Г.Гыйльманов

**Югалтып бетерү** Тәмам, тулысынча югалту; барысын да, бөтенесен дә югалту. *Ләкин шулай да калабыз үзенең борынгы йөзен югалтып бетермәде.* Ә.Еники. *Гомер юлының күп өлеше үтелгәнлеген аңлагач, дусларын һәм якыннарын югалтып бетергәч, ул, ниһаять, вакытның гына түгел, үз буынының, җанга якын кешеләрнең китә баруын тойды.* Р.Мирхәйдәров

**Югалтып килү** Әлегә хәтле, акрынлап, аз-азлап югалту; бер-бер артлы югалту. *Ул дөньяның мондый нечкә мәсьәләләрен тулысынча аңлау, тою, үз күңеле белән аларга тоташа алу сәләтен югалтып килә иде.* М.Вәли-Барҗылы

**Югалтып кую** Кинәт, көтмәгәндә югалту. *Хисамый белән Җәләйнең көрәш вакытында сүзгә килүләреннән, --- моңарчы саклап килгән дуслыкларын югалтып куюларыннан курка иде ул.* Н.Яһудин

**Югалтып тору** Кыска вакытка, вакытлыча югалту. *Син эчке дөньяңны да югалтып торырсың.* А.Тимергалин. *Шуны [язулы кәгазьне] кулына китереп тоттырганнан соң, Фәридә, кая барып бәрелергә белми, бермәлгә зиһенен югалтып торды.* Н.Кәримова

**ЮГАЛТУ** II *и.* 1) Күргән, кичергән зыян-зәүрәт, зарар, каза. *Югалтулар, табышлар хакында, моң, сагыш, сер хакында ул [Нәфисә] гына шулай әйтә ала...* Г.Гыйльманов

2) Үлем, һәлак булу очрагы. *Барлык өч батальон да алдагы бәрелешләрдә зур югалтулар кичергән.* Я.Шәфыйков

**ЮГАЛТУЛЫ** *с.* 1) Зыянлы, зарарлы; чыгымлы. *[ИлСаф] Зур сәхнәгә беренче тапкыр күтәрелеп, көчен сынап караганнан соң, эзләнүле һәм ачышлы, табышлы һәм югалтулы, сөенечле һәм көенечле шактый еллар узган.* Г.Шәйхи

2) Һәлакәтле, бәла-казалы; фаҗигалы, үлем-җитемле. *Соңгы еллар югалтулы булды: Хәниябез китте, Рөстәм Зәкуанны җырләдек...* Шәһри Казан

**ЮГАЛТУСЫЗ** *с.* **1.** 1) Зыян килмәгән, зарарсыз; чыгымнарсыз. *Минем өчен авыр момент булды, ләкин [бу] югалтусыз, отышсыз вариант иде.* Татарстан яшьләре

2) Һәлакәтсез, бәла-казалар, фаҗига, үлем-җитемнәр булмаган. *Бу [казларның муеннарын һавага таба сузып, каңгылдаша-каңгылдаша биюләре], күрәсең, исән-имин, югалтусыз көн өчен шатлык хисләре белдерү мизгеледер.* С.Поварисов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Берни югалтмыйча, зыян күрмичә, зарарсыз. *Вакытында чәчеп, вакытында югалтусыз җыеп алу – әйбәт нәрсә, билгеле.* В.Нуруллин

2) Һәлакәт, бәла-каза, фаҗига, үлем-җитем кичермичә. *Ул бүген шат иде: олы юл чатында торган авылны югалтусыз диярлек аклардан коткардылар.* З.Мурсиев

**ЮГАЛТЫК** *и.* **1.** Югалган әйбер, югалган мал. *Югалтыклар өстәлenә мөрәҗәгать итү*

**2.** *с. мәгъ.* Югалган, юкка чыккан; урыны билгесез, табылмаган. *Югалтык малга кайгырма.* Әйтем

**ЮГАЛУ** *ф.* 1) Кемнеңдер карамагында булган әйбере, милке саксызлык белән кайдадыр онытылып яки төшеп калып юкка чыгу, җуелу; урлану. *Берсенең бияләе югалган, анасы җир астыннан таптыра!..* А.Гыйләҗев. *Ишетсен колагы: берәр әйберем югалса, хәзер милиция чакыртам!* Ф.Яхин

2) Кайда ятуы билгесез булу, табылмау. *Бәхетенә күрәме, әллә инде тегеләрнең башка эшләре күп булдымы, әллә югалган сука белән вакланасылары*

*килмәдеме, ике милиционер бүтәнчә килеп борчымады.* Р.Низамиев. *Кызганыч, ул пистолет әллә югалды, әллә урладылар аны шунда.* А.Гыймадиев

3) Күзгә күренми башлау, күз алдыннан, күз күременнән юкка чыгу. *Аны [машинаны] бездән алда кабызып, ыргылып урыныннан кузгалды, юлда тезелешкән машиналар төркеме арасына чумып, шунда ук күздән дә югалды.* А.Хәсәнов. – *Тиз әйләнеп киләм, – диде дә, сукмак буйлап төшеп, тыкрыкка борылды, китеп тә югалды.* Ф.Яхин

4) Нәрсә дә булса эченә кереп күренмәс булу, яшеренү. *Тау кадәр трактор, утлары белән авыл урамын тутырып, буран эченә кереп югалган гына иде.* Г.Гыйльманов. *Ул [Миңлебай] караңгылык эченә кереп югалганчы карап торды.* Н.Яһудин

5) Каядыр китеп бару, билгесез якка һәм билгесез вакытка китеп юк булу, кайдалыгы мәгълүм булмау. *Кайсыдыр ягы белән тәэсир иткән бу кешенең шулай көтмәгәндә югалуы, бөтенләй юкка чыгуы аянычтан да аяныч иде.* М.Кәбиров

6) Адашу, юлдан язу. *Беләсездер, балалар, Урманда югалсалар, Ул кешегә ни диләр? Адашкан, мескен, диләр.* Р.Корбан

7) Озак килми тору, хәбәре булмау, очрамау, күренеп йөрмәү. *Аннан [телефоннан]: «Княгиня, сез кая югалдыгыз, нигә тавыш-тыныгыз юк?» – диган шелтәле тавыш ишетелде.* М.Әмирханов. *Югалды: ни кичке уенга чыкмый, ни су буена.* А.Фәләх

8) Үлү, вафат булу. *Югыйсә, олыгаяолыгая, таныш-белешләрнең арадан югалуына күнегә барасың...* Р.Зәйдулла

9) Үтерелү, һәлак ителү, бетү. – *Атасы мескен генә бәхетле көннәрне күрә алмады шул, – дип, Октябрь өчен булган канлы сугышларда югалган ирен хәтерләде.* А.Алиш. *Типсә тимер өзәрдәй йөзәрләгән ир-ат белән бергә аның этисе дә чит җирләргә чыгып югалды.* В.Имамов

10) Бетү, юкка чыгу. *Якты күлдәге кичәге дулкыннар каядыр югалганнар, камышлар да, шәмдәй булып, җиңү музыкасын тыңлыйлар.* А.Алиш

11) Качу, тиз китү, юк булу, бу урында башка күренмәс булу. *Бар, хәзер үк күземнән югалыгыз!* Н.Яһудин. *Мин исә, кызып китеп: «Хәзер үк яхшылык белән югал күз алдымнан!» – дип ыжгырып өстенә килә башлагач, кабат: «Вот псих!..» – дип, чигенә-чигенә китеп үк барды.* Казан утлары

12) *күч.* Билгесез булып калу, әрәм булу, эзсез бетү, үзеннән нәтиҗә калдырмау. *Син – деловой! Берчакта да Югалмассың син ансы...* Р.Миңнуллин. *Галимулла белән дуслык тотса, югалмас улы, югалмас.* Ф.Яхин

13) *күч.* Әрәмгә китү, әрәм булу, нәтиҗәсез юкка чыгу. *Кәгазьгә язылмаган гыйлем әрәмгә югала.* Мәкаль. *Яшәгән гомернең, мөгаен, күбрәк өлеше әнә шул кимегән көпшәк бозлардай файдасызга югала.* А.Вергазов

14) *күч.* Нинди дә булса рухи халәт, аерым бер сыйфат бетү, калмау, юкка чыгу. *Аның күңелендә мәхәббәткә, изгелеккә булган ышаныч югалды...* М.Кәбиров. *Йортыбызның яме югалды, нуры сүнде – чын ихластан әйтәм...* Г.Гыйльманов

15) *күч.* Билгеле бер эзлеклелеге, тәртибе китү, буталу. *Абыйсы кузгаткан сүзнең очы шуның белән югалды.* Ф.Садриев

16) *күч.* Бөтен игътибарны үз уена, борчуларына юнәлдереп, чынбарлыктан читкә китү. *Уйларында югалган Сабир да айныгандай булды, беләгемнән тотты, зурдан кубып сөйли башлады.* Ф.Яхин

**Югала бару** Торган саен күбрәк югалу; акрынлап, аз-азлап, бер-бер артлы югалу. *Зәңгәрсу офыкта югала барган теплоход шәүләсе...* М.Кәбиров

**Югала башлау** Югалуга таба бару; югалырга тотыну. *Сакалга чал кереп, буемның төзлеге дә югала башлаган.* Г.Ибраһимов. *Соңгы көннәрдә карт тагын каядыр югала башлады.* А.Алиш

**Югала тору** Һәрберсе, булган берсе югалу. *Диңгезчеләрнең калын олтанлы ботинкалары астыннан вак ташлар кубып, сикерә-сикерә, түбәнгә тәгәрәделәр, әкрен генә чайкалган дулкыннар эченә чулт итеп чумып югала тордылар.* Г.Әпсәләмов

**Югала төшү** Бераз, берникадәр югалу. *Сезнең текстта милли колорит ярлыланган, шуның өстенә комедиячел моментлар да югала төшкән.* Т.Гыйззәт

**Югала язу** Чак кына югалмый калу. *Күрәсең, апамның боегып калуы минем, югала язып, әти-әниемне хәсрәткә салуда гына түгел.* Т.Нурмөхәммәтов

**Югалып алу** Азга, кыска вакытка югалу. *Килгән егетләр каядыр югалып алалар.* Т.Галиуллин

**Югалып бетү** Барысы да югалу; тулысынча югалу. *Аның яшьлек елларында иҗат иткән төрле сюита, экспромтлары нотага салынмаган, ил буйлап гастрольләрдә йөргәндә таралып, югалып беткәннәр.* Л.Хәмидуллин. *Туганнарым кайсы кая югалып беткән, кайсы башка дөньяга китеп барган...* Г.Гыйльманов

**Югалып йөрү** Әле, хәзерге вакытта, кайдадыр югалу. *Үзең, эшләүчеләргә салкын әйрән алып киләм, дип киттең, ә үзең әллә кайларда югалып йөрисең, тинтәк малай!* Н.Яһудин

**Югалып калу** 1) Бөтенләй, кайдадыр югалу, юкка чыгу. *Әмер гүләп килгән җил эчендә югалып калды, мизгел дә үтмәде, ком өермәсе кояшны йотты, җиһан караңгылыкка чумды.* М.Әмирханов

2) *күч.* Аптырашка төшү, нишләргә белмичә тору, каушау. *Көтелмәгәндә килеп кергән апасы алдында ул тәмам югалып калган иде.* Ф.Яхин

**Югалып килү** *к.* **югала бару**. *Мондый чакта инде югалып килгән яучылык традициясе турында ничек искә алмыйсың!* Сөембикә

**Югалып кую** Кинәт, көтмәгәндә югалу. *Юк, юк, Мөхәммәт бабай, кешенең күз карасы кебек әйберен ничек курыкмыйча юлга аласың ди. Югалып куйса.* Ф.Яруллин

**Югалып тору** Бертуктаусыз, һаман, гел югалу; әлегә, вакытлыча югалу. *Бала белән юанып алгач, күңеле бераз тынычланып киткәндәй булды, тынгысыз уйлар югалып торды.* Н.Фәттах. *Шул китүеннән ул ун көннәр чамасы югалып торды.* А.Хәсәнов. *Ә менә күрше-тирә кетәклекләрдән тавыклар югалып тора икән.* Г.Гыйльманов

**ЮГАЛУЧАН** *с.* Тиз югала торган, югалу гадәте булган. *Бәйрәм кәефе – бәйрәмнең үзе белән бергә узып югалучан вакытлы хәл.* Ш.Галиев. *Ә җепнең очы чуалучан, югалучан.* Ватаным Татарстан

**ЮГАРТЫН** *рәв. сөйл.* 1) Югарыдан, биектән; югарыда булган килеш, биектә торып. *Югартын, бик югартын пар-пар тургайлар сайрап, көмеш тавышлары белән табигатьне күмәләр.* Н.Думави. *Бөркетләр очалар югартын!* И.Юзеев

2) Өске ягыннан, башыннан, очтан, очыннан гына. *Аларда, гомумән, «ашлык эскерте» дигән төшенчә булуына шигем бар, чөнки, чыганакларга караганда, Борынгы Мисырда ашлыкны урганда да бик иелеп тормаганнар, югар-

*тын урганнар, һәм басуда озын, биек камыл кала торган булган.* А.Тимергалин

3) *күч.* Мактанып, бик һавалы кыланып; өстән генә, артык җентекләп тормыйча. *Бик югартын күз салырга башладык әхлакка без, Кер күңелдә күплегеннән бармыйбыз ак якка без.* Г.Тукай

◊ **Югартын очу** 1) Зур максатлар кую, бөек хыяллар белән яшәү. *Яшь чагында күңел кошы бик югартын оча иде, Болытларга канат җилпеп, йолдызларны коча иде. Оча иде, канат талды, кунаклады түбәнгәрәк.* Г.Афзал; 2) Бик югары таләпләр кую; тәкәббер кылану, үзен эре, һавалы тоту, кәпрәю. *Кыз халкы, --- матуррак та булса, бигрәк тә югартын очарга тели.* Ш.Маннур. **Югартын торып** 1) Гомуми нәтиҗә чыгарып, фәлсәфи фикер йөртеп. *Иптәшләренең, дус һәм таныш кызларының өметен җимермәс өчен, Фатихка югартын торып, акыллы сүзләр генә сөйләргә, фәлсәфәгә чумарга кирәк иде дә, характеры андый түгел.* И.Нуруллин; 2) Үзен башкалардан өстен куеп, тәкәббер тотып. *Күрәм: син [Закир], элеккечә үк, бик югартын торып сөйләшәсең кешеләр белән.* Ф.Хөсни

**ЮГАРЫ** *с.* **1.** 1) Гадәти өслектән биектәрәк торган, өстәрәк урнашкан. *Кичке эңгер-меңгер зәңгәр күктә йөзгән кояшны тау ягының югары очында дулкын-дулкын булып яткан калкулыклар артына яшерде.* А.Фәләх

2) Чагыштырмача биегрәк якта урнашкан (урам, җирлек тур.). *Мәрьямбикә карчык сүз җебен үз кулына алды, югары очтан башлап түбән очка кадәр өй борынча йөреп чыкты.* А.Гыйләҗев. *Малайлар югары оч Әбүзәрнең Әлмәттән әллә нинди кәтүкле кармак алып кайтканын үз күзләре белән күргәннәр.* А.Тимергалин

3) Зурлыгы билгеле бер дәрәҗәдән артып киткән, күләм, сан күрсәткече күп булган. *[Әбүзәрнең] Иреннәре чыбырган, температурасы югары.* А.Тимергалин. *Шушы көннәрдә кызык өчен генә мәктәбебезнең ул эшләгән елларда спортның төрле юнәлешләрендә район, республикада алган урыннарын барлаган идек, үзебез дә аптырап калдык: гаҗәпләнерлек югары саннар килеп чыкты.* Ватаным Татарстан

4) Административ баскычта өстә торган; өске, баш. *Мәскәүнең югары органнары карары белән, Бөек Ватан сугышы чорында тылда батырлык күрсәтүчеләргә Җиңүнең 30 һәм 40 еллыкларында юбилей медальләре бирергә, дигән карар чыгарылды.* Р.Зарипов. *Әлбәттә, шундый югары урын билгән, бөтен бер республика өчен җаваплы дәүләт кешесенең уйлары да вак-төяк түгел иде.* И.Хуҗин

5) Төрле уку, осталык, белем баскычларында соңгы, өлкән. *ФЗӨдә кызның сәләтле булуын бик тиз күреп алалар һәм Гөләндәмнән югары квалификацияле кием кисүче – модельче әзерлиләр.* А.Тимергалин. *Төп рольләргә яшь, әле генә югары белем алган яки алып яткан көчләрне билгеләп, алар белән эшләве дә – нәкъ менә аның [режиссёрның] кыюлыгы да, зур иҗат уңышы да!* А.Әхмәдуллин

6) *лингв.* Шигъри, китапча, сәнгатьле, аеруча нечкәлек, пафос белән сыйфатланган (стиль, тел, сөйләм тур.). *Сөембикәнең Казан белән бәхилләшүе дә Атласи тарафыннан югары стильдә, көчле хиссият белән, нәфис әдәби телдә язылган.* Ф.Бәйрәмова

7) Кыйммәте, бәясе, төшеме һ.б.ш. күбрәк, артыграк булган. *Әсир солдат Германиядә югары хак түләнә торган эшкә ничек керә алсын инде?* Т.Әйди. *Тик менә югары такса куеп, акча җыюы гына ошамый.* Г.Гомәр

8) Яхшырак, әйбәтрәк, файдалырак, уңышлырак. *Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры иң югары сыйфат белән реставрацияләнде.* Р.Вәлиев. *Югары уңыш алыр өчен, басуларны бүгеннән үк тәрбияли башларга кирәк.* Ә.Әминев

9) Нәтиҗәлерәк, өстенрәк торган, күтәренке. *Даирәсенә дә, үзенә дә күп очракта акланмаслык югары таләпләр куя.* М.Әмирханов. *[Айдар] Менә инде дистә елдан артык иң абруйлы [татарча көрәш] ярышлар[ын]да югары нәтиҗәләр яулый.* Г.Мөхәммәтшин

10) Үсешнең иң киеренке, иң каршылыклы ноктасына җиткән; кульминацион. *Озак та үтмәде, Сабан туеның иң югары ноктасы булган олылар көрәше башланып китте.* Н.Көбәш

11) физ. Көчле, зур көчәнешле. *Безнең басулар аша ике җирдән югары вольтлы электр чыбыклары үтә.* А.Гыйләҗев. *[Сыгылмалы тирәлек динамикасы теориясе] --- югары басым күп файдаланылган шартларда конструкцияләрнең чыдамлыгын билгеләүне җиңеләйтә.* Т.Әйди

12) Нечкә һәм яңгыравыклы. *Фәридә шунда ук югары тавыш белән җыр башлады.* И.Салахов. *Ташкындай көч, я бәллүрдәй үтәкүренмәле югары авазларны челтәрдәй итеп үрә алу зур осталык, профессональ югарылык сорый.* Ватаным Татарстан

13) Олы, өлкән. *Концертка урта һәм югары буын татар тамашачылары да күп килгән.* Татарстан яшьләре

14) **югарыдагы** *кит. у.-вак. килеш форм.* Алда әйтелгән, алда күрсәтелгән, моңа кадәр китерелгән. *Төшем килеше исә, югарыдагы мисаллардан күренгәнчә, һәрчак билгеле объектка күрсәтә һәм үзе бәйләнгән сүздән теләсә нинди ераклыкта урнаша ала.* Ф.Хисамова. *Югарыдагы мисаллар күпьеллык педагогик тәҗрибәмнән алынды.* Х.Гарипова

15) Билгеле бер өлкәдә кайсы да булса сыйфаты белән алдарак торган, яхшырак булган, зур үсешкә ирешкән; катлаулылыгы, кыйммәте, дәрәҗәсе һ.б. ягыннан өстен булган. *Урта диңгез бассейнында югары культура чәчәк аткан чорларда дәүләтнең үзәге Крит түгел, бәлки Платон тасвирлаган Атлантида утравы булган.* Н.Фәттах. *Нинди камиллек, нинди югары пилотаж... Безгә, хәрби очучыларга, әле өйрәнергә дә өйрәнергә генә икән кошлардан.* Р.Мөхәммәдиев

16) Иң әйбәт, шәп, уңай. *Ул [Боэций] музыканы форма ягыннан карый, һәм замандашлары аның [«Музыка турында» дип аталган] трактатына югары бәя бирәләр.* К.Гыйззәтов. *Эстоннарның үзләре хакында югары фикердә булуларына да җирлек бар – хезмәт сөючән, рухи тормыш белән яшәргә омтылучан горур милләт ул!* Т.Әйди

17) Иң катгый, иң каты, иң кискен. *Революция өчен шулай кирәк, дип исәплисез икән, иң югары җәзага тартыгыз – атыгыз мине.* Р.Мөхәммәдиев

18) Ялкынлы, күтәренке рухлы, көчле. *Зөләйха образында ул [Гаяз Исхакый] бу батыр хатынның бөтен язмышын билгели, аның үз дине өчен алып барган тиңдәшсез көрәшен югары пафос белән сугара.* А.Әхмәдуллин

19) Зур хөрмәт күрсәткән, олылауны белдергән; хөрмәтле, ихтирамга лаек, олы, бөек. *Халык аңа үзе исән чагында ук «кануни», «шәүкәтле» дигән югары исем-атларны нигезсез көе, тиктомалдан гына такмагандыр.* В.Имамов

20) Иң кырыс таләпләргә җавап бирерлек, камил. *Сүз сайлауда, сүз тәртибендә, җөмлә төзелешендә, өслүбнең*

*сыгылмалылыгында һәм нәфислегендә Коръән аятьләре шагыйрьләр һәм, гомумән, әдипләр өчен иң югары зәвык үрнәге булып тора.* А.Тимергалин

21) Дәрәҗәсе, тоткан урыны белән өстен булган, абруйлы, авторитетлы. *Югары даирәгә мөнәсәбәтле һәр бекле мирза олуг кенәзгә ярлык җибәрүне үзенең асыл бурычы сыйфатында кабул кылды.* М.Әмирханов. *Аннары, хатта әйтелгәндер, сез Аттила янына иң югары санлы илче – магистратлардан торган делегация җибәрергә тиешсез.* З.Хәким

22) Зур мал-мөлкәткә, байлыкка, күп акчага ия булган, бай. *Югары катлау кулланган тәсбихләр асыл ташлардан ясалган була.* А.Тимергалин

23) Тормышның матди ягына карамаган, саф рухи, күңел, рух, җан белән бәйле. *Ул [борынгы кеше] киек хайванны уңышлы аулау һәм дошман белән көрәштә аны җиңеп чыгуга гына түгел, бәлки дуслык, оешканлык, мәхәббәт кебек югары хисләргә дә шатлана белә торган булган.* К.Гыйззәтов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Өскә, өскә таба; *киресе*: **түбән**, **түбәнгә**. *Рәфис, агачлар ышыгында басып торган килеш, ике кулын югары күтәреп, киерелеп, тирән сулыш алды.* А.Вергазов

2) Үргә таба, текәлек өстенә, өстәрәк урнашкан җиргә. *Мостафа, таш араларындагы ярыкларга тотынатотына, югары үрмәләде.* Г.Әпсәләмов

3) Офык читеннән биеккәрәк, горизонттан өскә таба. *Кояш югары менеп киткәч, һава җылынып җиткәч, [бал кортлары] көтүләре белән, бергәләшеп, җиң сызганып, күмәкләшеп эшкә ашыгалар.* А.Алиш

4) Баш очыннан өстә, биектә, биеклектә. *Мартта болытлар тиз һәм югары йөзсә – көн яхшырыр.* Сыналмыш. *Яшь шагыйрьләр үтә образлы язалар, аларның шигырьләре --- Сабантуй сөлгесе сыман һәрчак бик югары эленгән була.* Р.Вәлиев

5) Агымга каршы юнәлештә, елга, инешнең башына, башланган урынына таба. *Сөләйман гаскәрләре Дунайның ике яры буйлап югары күтәрелә башлагач та, күрше каһанлыкның солтанына бүләк тә юлламыйча, король булырга чамалаган Фердинанд Будадан Венага чыгып качкан.* В.Имамов

6) Түргә, чыгу юлыннан эчкәрәк, алгарак үтеп. *«Әй углым, --- үзеңнән олуглар барында алардан югары утырма, пакь, нәфис җирләргә төкермә», – дип, тәнбиһ вә васыять итмештер ки.* К.Насыйри

7) **югарыда** *кит. у.-вак. килеш форм.* Текстның, сөйләмнең алдагырак өлешендә, шуңа кадәр (искә алыну, әйтелү, язылу тур.). *«Идегәй» дастаны – югарыда әйтеп үтелгән урта гасыр татар (болгар) шагыйрьләре тарафыннан язылган әсәрләрдән үзгә буларак, тарихи фактлар нигезендә иҗат ителгән эпос.* К.Гыйззәтов

8) Нинди дә булса сыйфаты, үзенчәлеге белән өстенрәк, яхшырак, дәрәҗәлерәк итеп. *Сәяхәтче һәм күзәтүчән шаһит буларак, ул [Гобәйдулла Әмиров] мәшһүр Исмәгыйль агадан да һәм, әгәр инде руслар белән чагыштырыйк дисәк, атаклы Афанасий Никитиннан да югары тора.* А.Тимергалин

9) Уңай рәвештә, яхшы дип табып. *Борынгы римлылар грек әдәбиятын югары бәялиләр.* К.Гыйззәтов

**3. югарылар** *и. мәгъ.* 1) Хакимият органнары, җитәкче оешмалар. *Блок башлыгы, үзеннән югарылар белән сөйләшеп алгач, Мусага кабинетына яндаш буш бүлмәне тәкъдим итеп, өенә китте.* Ш.Маннур. *Кулыңнан килмәгәч, нигә начальник итеп сине тоталар соң? Югарылар күрми микәнни?* А.Гыйләҗев

2) Дәрәҗә, абруй яки байлык белән өстен торган катлау. *Үзеңнән түбәннәргә карап шөкер ит, югарыларга карап фикер ит.* Мәкаль

3) Абруй яки байлык китерә торган шартлар, шундый тормыш дәрәҗәсе; өстенлек, камиллек. *Ир кеше, Фәридә ханымның фаразынча, нәкъ менә шушындый сыйфатларга ия булырга тиеш иде: дәрәҗә сөйсен, югарыга омтылсын, нинди генә гамәл кылса да, әүвәле – гаиләсенә һәм милләтенә файда өчен тырышсын.* Ф.Яхин

◊ **Югарыга юл алу** *к.* **югары күтәрелү**. *Мин тормышта һаман яктыга, Югарыга таба юл алдым.* Һ.Такташ. **Югарыдан карау** Һавалы булу, үзен башкалардан өстен санау, зурдан тоту. *Һаҗәрнең һәммәгә югарыдан карый алырлык бикә мәртәбәсенә ирешүе күпләрнең эчен яндырды.* Г.Ибраһимов. **Югарыдан очу** *к.* **югарыдан карау**. **Югарыдан узу** *к.* **югары узу**. *Ул, килеп кереп, сәлам бирү белән --- мәҗлестәгеләр берьюлы ачык сүз белән каршыладылар: – Ә, Кәрим мәхдүм, синме?.. Әйдүк, югарыдан уз...* Г.Ибраһимов. **Югары күтәрелү** Дәрәҗәгә, максатка ирешү, абруй, дан казану, камилләшү, үсү. *Укып гыйлем һәм дәрес юлында дәвам иткәннәре күп югары күтәрелеп, башкалардан шактый оста булалар.* Г.Баруди. **Югары узу** Түргә килеп утыру, хөрмәтле урынга узу

**ЮГАРЫГЫ** *с.* 1) Югарыда булган, биек урында урнашкан; өстә торган. *Палач, килеп тукталу белән, алдан әзерләп куелган урындыкка менеп, дар агачын, аның югарыгы башында җеп эләктергән җирен карады.* Г.Ибраһимов. *Аклыкта коенган ак каенның иң югарыгы ботагына ап-ак түшле, озын ак койрыклы купшы бер кош килеп кунды.* Р.Мөхәммәдиев

2) Өске, нәрсәнеңдер өске ягында урнашкан. *Барлыгы ике тәрәзә, аларның да тик иң югарыгы өлгеләре генә җирдән өскә күтәрелгән.* Г.Ибраһимов. *Югарыгы катларның берсендә кемнеңдер йөргәне, аның башмак тавышлары ишетелде.* Ф.Яхин

3) Елга, инешнең башына, башланган урынына якын торган. *Казан тәхетенә --- Сәхиб Гәрәй менүе белән исә филвакыйг Казан вә Кырым берләшкән, шуның аркасында Идел буеның югарыгы агымы Госманлы империясе кулына кергән иде.* Г.Гобәйдуллин. *Әмма бу --- боз түгел әле, кайдадыр елганың югарыгы агымында яуган карның, салкын суда эремичә, ботка кебек куерып килә башлавы гына.* С.Сабиров

4) *күч.* Алда әйтеп, күрсәтеп үтелгән, мәзкүр. *Бу – минем өчен бер сабак булса да, мин тагы, югарыгы сәбәпләр өчен, Яушырмәдән китә алмадым.* Г.Исхакый

5) *күч.* Бай, барлыклы; авторитетлы, абруйлы, дәрәҗәле; югары даирәгә караган. *Кайчан бер падишаһ сине тиңдәшләреңнән артык сыйлады һәм кадер, мәртәбәңне иң югарыгы баскычка җиткерде.* Ибн эл-Мөкаффаг. *[Фатих Әмирхан] Хаҗи сурәтен һәм аның башкаларга мөнәсәбәтен бирүдә үзенең югарыгы катлау буржуага апатиясен күрсәтми кала алмый.* Һ.Такташ

**ЮГАРЫЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн.* Торган урыныннан югарырак күтәрелү, югарырак торыш алу. *Кояш югарылана, көн кызганнан-кыза бара.* Г.Ибраһимов

2) Үсү, арту. *Хезмәт хакы югары икән, таләпләр дә югарылана бит.* Безнең гәҗит

3) *күч.* Дәрәҗәсе, белеме, әзерлеге күтәрелү. *Елдан-ел тәҗрибәсе югарылана*

4) *күч.* Ләззәтләнү, хозурлану, хушлану. *Күңел югарылана гали хис берлән.* М.Гафури

**Югарылана бару** Торган саен күбрәк югарылану. *Бу эшләрдән соң минем фикерем югарылана гына бара...* М.Гафури

**Югарылана башлау** Югарылануга таба бару. *Кояш, кызуын арттырып, югарылана башлады*

**Югарылана төшү** Тагын да югарылану

**ЮГАРЫЛАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **югарылау**, югары итү, югарыракка күчерү

2) *күч.* Кемнең дә булса каршында абруен күтәрү, мөнәсәбәттә хөрмәт күрсәтү, дан өстәү. *Бу сүзләргә Җәләш мулла үзе дә ышана башлап, шул вакыйгалардан соң, ул балаларына карашын югарылата, өмитен зурайта.* Г.Ибраһимов

**Югарылата бару** Торган саен күбрәк югарылату. *Үткән һәрбер минут аның [кояшның] урынын югарылата бара.* Г.Ибраһимов

**Югарылата төшү** Тагын да югарылату

**Югарылатып җибәрү** Бераз югарылату; кинәт югарылату

**ЮГАРЫЛА́У** *ф.* 1) *к.* **югарылану**. *Кояш Урал тауларының артыннан күтәрелеп югарылаган саен, тирә-як тагын да киңрәк, тагын да ямьлерәк булып күренә.* Г.Ибраһимов

2) *сөйл.* Югарыгарак, биеккәрәк күтәрү

3) *күч.* Кемнең дә булса дәрәҗәсен, абруен күтәрергә тырышу, чынбарлыктан югарырак мактау. *Югарылавыгыз юш килсен!* Әйтем. *Борынгы язучыларның күбесе хакимнәренең гамәлләрен купертеп язган һәм үз патшалыкларын югарылаган.* Безнең гәҗит

**Югарылый бару** Торган саен күбрәк югарылау

**Югарылый төшү** Тагын да югарылау; бераз югарылау. *Картинаның уң почмагын югарылый төш*

**ЮГАРЫЛЫК** *и.* 1) Җирдән, баш өстеннән югарыда булган пространство, биеклек. *Әллә ничек шунда, кинәт кенә күк капусы ачылып киткәндәй итә, иксез-чиксез югарылыкта тагын нindидер икенче бер дөнья чагылып киткәндәй була.* М.Хәсәнов

2) Югарыда, биеклектә алган урын. *Артта самолётның кузгалып киткәне, әкренләп югарылык алганы, тора-бара бөтенләй ишетелмәслек булып еракка очып киткәне ишетелә.* Т.Гыйззәт

3) Югары булу сыйфаты. *Безнең җырларны җиренә җиткереп башкару – нотадагы югарылыкларны алу, билгеләрне тавышка күчерү генә түгел, аңа җан өрергә, тормыш сулышы бирергә кирәк.* Ф.Хатипов

4) *кыек килешләрдә* Биеклеккә, өскә таба билгеле бер тәңгәл, чик. *Мадераның тарихи истәлекләре арасында иң атаклысы – текә таш кыя битлегенә, егерме биш метр югарылыкка, рельефлы итеп эшләнгән җайдак сурәте, әлбәттә.* Казан утлары. *Фотолар квадрокоптер ярдәмендә кош очар биеклектән, ягъни 35 метр югарылыктан төшерелгән.* Кызыл таң

5) *күч.* Ирешелгән уңай сыйфат, уңыш, куелган таләпләр һ.б. дәрәҗәсе; югары сыйфатлылык. *Анда яңа заман авазы белән сугарылган классик музыка галибанә яңгырап бүлмәне тутырды. Нинди бөеклек, югарылык...* М.Мәһдиев. --- *сәнгать кануннарына таянып иҗат иткән Б. Урманче татар сынлы сәнгатен Аурупа күләмендәге югарылыкка күтәрде.* М.Хәсәнов

6) *күч.* Тоткан урын, дәрәҗә. *Хәзер бу сорауны федераль югарылыкта караячаклар.* Шәһри Казан // Фикерләү, мәдәниятлелек дәрәҗәсе. *Борынгы кешеләрне үтә кыргый дип санаган һәм аларга үз югарылыгыннан торып, масаеп караган Европа кешеләре галимнең ачышына ышанмыйлар.* Г.Дәүләтшин

7) *күч.* Абруй, бөеклек. *Менәргә ярдәм ит, минем, бик аз гына булса да, Сөләйман югарылыгына күтәреләсем килә.* И.Юзеев

8) *күч.* Югарыдан караучанлык. *Форсат чыкканда, мөмкинлегең булганда, хатыныңның «юк акчаны әрәм-шәрәм итеп, бушка туздырып йөрисең» дип фырылдавына да исең китмичә, үзеңне тиешле югарылыкта тотып, таксида гына йөрергә тырыш.* М.Мәһдиев

**ЮГАРЫЛЫКЛЫ** *с.* Югарылыкка ия булган. *Бөтен йөрәкне шундый бер ләззәт чолгап алды ки, андый ләззәтне дәртле, моңлы, югарылыклы, ләкин тәҗрибәсез яшьлек кенә татый ала.* Ф.Әмирхан

**ЮГАРЫЛЫ́-ТҮБӘНЛЕ** *с.* **1.** Аслы-өсле, төрлесе төрле биеклектә булган, берсе икенчесе өстенә урнашкан. *Кәнсәләрнең югарылы-түбәнле өч киштәсендә тырнак басарлык буш урын юк.* Ш.Камал

**2.** *рәв. мәгъ.* Бер югарыга, бер түбәнгә, бер ягы югарыга, икенче ягы түбәнгә һәм киресенчә алмашынып. *Бармаклары гармун телләреннән югарылы-түбәнле йөгерде*

**Ю́ГЫЙСӘ** *терк.* **1.** 1) Кушма җөмләдәге сәбәп яки нәтиҗә җөмләне баш җөмләгә бәйләү өчен кулланыла. *Димәк, фаҗигa Рәхимнең башына яңа җитәкче уйлаганнан катырак суккан, аңын томаландырган, югыйсә ул, әлеге сәбәпне аңласа, бәлки, буталыштан чыгу җаен күптән табар иде.* М.Хуҗин

2) Ихтимал булган сәбәпләрне белдергән җөмләне гаҗәпләнү-сорау төсендә бирелгән баш җөмләгә бәйли. *Адәм баласына гайрәт көчен Аллаһы Тәгалә үзенең рәхмәт нурыннан алып бирсә кирәктер, югыйсә каян килер иде аңа кызгану хисе*? М.Хәбибуллин. *Дошманга ишарен сигнал бирүче диверсантлар да бар бугай, дип сөйләнгәннәр иде – хак, ахрысы, югыйсә каян килеп алар бомбаларын шулай төгәл ташларлар иде?* Х.Камалов

3) Гомуми, гадәти, закончалыклы күренеш икенче бер гадәти булмаган күренешкә каршы куелган иярчен җөмләне баш җөмләгә яки контекстка бәйләү өчен кулланыла. *Каравылчы Габбас атның ак күбеккә батып, әсәренеп, алакаеп кайтып керүенә гаҗәпләнә, югыйсә Вениамин абзый малны каулый, куа торган кеше түгел.* В.Нуриев

4) Килеп чыгу ихтималы булган тискәре, теләмәгән хәл-вакыйгадан, начар нәрсәдән, хәвеф-хәтәрдән кисәтүне белдергән иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйләү өчен кулланыла. *Хурлама мине алай, югыйсә икмәк шүрлегеңә менеп төшәргә дә күп алмам.* Р.Ишморат. *Тик менә шимбә-якшәмбеләрдә эшләргә туры килер, югыйсә җәйге сезон башланганчы өлгертеп булмас.* А.Тимергалин

5) «Киресенчә булса» мәгънәсендә кулланыла. *Мин әзрәк сизенәм: гади генә карт түгел бу бабай, югыйсә әти аны озатып куярга атын бирмәс иде.* А.Хәсәнов

6) *сир.* Яисә. *Завод ябылган тәкъдирдә, выходной пособие ике атнагамы югыйсә айлыкмы бирелә?* Ш.Камал

**2.** *кис. функ.* 1) Сорау төсмере белдереп, «әллә», «соң» кебек кисәкчәләрне көчәйтеп килә. *Беләзегем Филисә, Арасыннан җил исә; Иртә исемдә, кич төшемдә – Насыйп мәллә югыйсә.* Җыр. *Әллә югыйсә әдәбият, элекке*

*тылсымлы тәэсир көчен югалтып, дәрәҗәсен төшердеме? Арзанаеп калдымы?* Г.Бәширов

2) Хәбәрнең яхшы мәгълүм булганлыгына ишарә итеп, аны кабат раслау төсмере белән фикерне куәтләп әйтелә; бит, ич. *Җил дә бар югыйсә, тик ул да болытларны сөреп алып китми, безнең түбәдә генә болгандырып йөртә.* А.Гыйләҗев. *Аның күрше кызы Лилия белән дус булып йөрүен дә, иртәләрен мәктәпкә бергә баруларын да беләсең югыйсә.* А.Гыймадиев

**ЮГЫН** *и. диал.* Юынтык су. *Югын барда чебен бар, Чебен барда чирең бар.* Мәкаль

**ЮГЫНДА** *рәв. сөйл.* **1.** 1) Юк чакта, булмаганда. *Тәрәзәне Һади әнисе югында ясап куяр.* А.Гыйләҗев. *Сез югында Шәмсүн абый да килә монда.* А.Вергазов

2) Булмаганга, булмау сәбәпле, булмау нәтиҗәсендә. *Ит югында үпкә дә тансык, дип тынычланудан ни файда!* Б.Рәхимова

3) Булмаган хәлдә, булмаганлыктан. *– Кеше югында йоклап ал, – диде абыйсы.* М.Галәү

**2.** *кис. мәгъ.* Бер дә булмаганда, һич югы. *Сөйлә син, хет югында, нидер сора, башыңны как...* Р.Мөхәммәдиев

**ЮГЫННАН** *рәв. сөйл. к.* **югында** (*2, 3 мәгъ.*). *Эш югыннан эш табып йөри, дип ялгышалар: Ярмөхәммәт, ялгыз җанын кая куярга белмәгәннән, үзе шулай шөгыль таба.* Р.Батулла. *Өй каршындагы агачлар, җил югыннан файдаланып, черем итеп алмакчы.* Р.Кәрами

**ЮГЫЧ** *и.* 1) Ни дә булса юа торган чүпрәк. *Беренчедән, кешенең психикасы шундый: ул синең мохтаҗлыгыңны күрә, синең эшең, карьераң, язмышың үзенә бәйле икәнен белә, син аңардан башка беркая да китәлмисең, шунлыктан ул сине югыч итеп сыга, үзенә максималь файда чыгара.* З.Мурсиев

2) Савыт-саба кебек нәрсәләрне юу өчен үреп ясалган махсус челтәр мунчала яки башка шундый предмет. *Тагын юыгыз, югыч белән ныграк ышкыгыз, дип боерды пешекчеләр бригадиры; күпме маташсалар да маташтылар, әмма үз дигәннәренә ирешteләр: берничә сәгатьтән зур чуен казаннар балкып утыра иде.* З.Мурсиев

3) Алдыннан килгән сүздә әйтелгән әйберне юа торган берәр төрле җайланма яки техника. *– Әнә сабын, менә сөлге, – диде һәм кул югыч өстендәге кечкенә шүрлектә торган кырлы стаканга ияге белән генә ымлады.* Ә.Еники. *Менә, тормыш нәкъ шәһәрчә: суы, уты, газы, канализациясе, телефоны, телевизоры – барчасы да бар, кер югыч машинасы да бар хуҗабикәнең.* М.Миначев

**ЮДЫРГЫЧ** *с. махс.* Юдырта торган. *Пластмассадан ванналар, юынгычлар, сифоннар, юдыргыч баклар, вентилятор детальләре, су краннары һ.б. җитештерелә.* З.Камалова

**ЮДЫРТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **юу**. *Башта әнкәй миннән идәнне юдырта. Аннан җәймә, җәймә өстенә зур ашъяулык җәеп, ике табаклык аш әзерли идек.* Э.Шәрифуллина

2) Өстенә сыеклык бөркеп, сиптереп, тузанны, пычракны агызып җибәрү, юып төшерү. *Җылы җәйге яңгырлар тагын яварлар да, бөдрә бәпкә үләннәрен изеп, саргайтып яткан дәү, кара [балчык] кисәкләрне юдыртып алып китәрләр...* А.Гыйләҗев. *Гангрена башланмасын өчен, кадак кергән ярашы мең шушы сыекча белән юдыртырга кирәк.* А.Хәсәнов

3) *күч.* Законсыз кулга төшерелгән акчаны рәсмиләштерергә, әйләнешкә кертеп җибәрергә тырышу. *Мәскәү дә әҗәтле булып калмады: хәрәмләшү, акча юдыртып алу һәм Русиядә хакимиятне көч ярдәмендә кулга төшерергә омтылуда гаепләп, аны ике мәртәбә төрмә срогына хөкем иттеләр.* Мәдәни җомга

4) *күч.* Җәмгыятьтә таралган фикерне юкка чыгару. *4нче декабрь сайлаулары алдыннан журналистларның миләрен тагын бер кат юдырту өчен, махсус сәбәп табып оештырылган семинар дип кабул иткәндер бу җыенны журналистлар.* Безнең гәҗит

**Юдырта бару** Һәрберсен, булган берсен бер-бер артлы юдырту

**Юдырта башлау** Юдыртырга керешү. *Әхмәров абзый атларны аз гына ярга таба чыгартты да, һәрберебезгә чыпта кисәкләрен тоттырып, атларны юдырта башлады.* Т.Нурмөхәммәтов

**Юдырта бирү** Бернигә карамый юдыртуны дәвам итү

**Юдырта төшү** Тагын да ныграк юдырту

**Юдыртып алу** Тиз генә юдырту. *Тез башлары чыгып, бөкшәеп торган чалбарны әнкәйдән юдыртып алдым.* Ф.Латыйфи. *Вакытым тыгызрак булса да, машинамны юдыртып алдым.* Безнең гәҗит

**Юдыртып бетерү** Барысын да, тулысынча юдырту; тәмам агып төшкәнче, агып киткәнче юдырту. *Дөрес, яңгыр азрак яуды инде, әмма күп яуса да – зыянга, чөнки чәчәкләрне юдыртып бетерә.* Шәһри Казан. *Тәрәзәләрне юдыртып бетерү*

**Юдыртып йөрү** Хәзерге вакытта юдырту белән мәшгуль булу. *Әстерхан татарларында җиңгә кеше, яшь киленнең сулыгын (сөлгесен) җилкәсенә салып, туй кунакларының кулларын юдыртып йөри.* Сөембикә

**Юдыртып калу** Форсаттан файдаланып юдыртырга өлгерү. *Өеңне дә юдыртып калмыйсыңмы соң?* Хезмәт даны

**Юдыртып кую** Тиз генә юдырту; алдан юдырту. *Савым төгәлләнгәч, сыерлар үз ятакларына чыгып китә, ә савым корпусын, ялт иттереп, махсус шланглардан кайнар су сиптертеп юдыртып куялар.* Кызыл таң

**Юдыртып ташлау** Тиз генә аннан-моннан юдырту; юдыртып агызып юкка чыгару. *Болгарлар пайтәхетен Чыңгыз Үргәнечне суга батырган шикелле җир өстеннән юдыртып ташлар идең дә, боларның Амудәрья кебек шашкын елгасы юк.* В.Имамов

**Юдыртып тору** Һәрвакыт, гел юдырту. *Ике метр буйлы, таза, сапсары чәчле урыс егете Павлов тын да алдырмый – аппаратураны чистарттыра, идәннәрне гел юдыртып тора.* З.Хәким

**Юдыртып чыгару** Башыннан ахырына кадәр, барысын да юдырту. *Идән юыла торган көн булмаса да, сестра идәнне юдыртып чыгара.* А.Шамов

**ЮДЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **юу**. *Керләрен кемнән юдыра, шул карчыгыннанмы?* Т.Гыйззәт. *Раббани аннан-моннан эшләгәнне яратмый: савыт-сабаны кат-кат юдыра, хәтта идәннәрне, ошатмаса, икенче тапкыр юдыра иде.* Г.Әпсәләмов

2) Юарга мөмкинлек бирү; су салып торып юарга ярдәм итү, юындыру. *– Ятма сөрхәнтәй булып, үсмәссең тәтәй булып, – дип такмаклый-такмаклый, мине урыннан кубарып, битне юдыра, табынга утырта.* Ш.Маннур. *Мәймүнә апа кулны-битне сабынлап юдыра, үзе комганнан су салып тора.* Татарстан яшьләре

3) *к.* **юдырту** (*2–4 мәгъ.*). *Язын су агымы текә ярларны юдыра, шунлык-*

*тан алар ишелеп төшәргә мөмкин*. Кызыл таң

4) *куч.* Нәрсәнең дә булса составын таркатып, химик элементларны аерып чыгару. *Тозлы азык ашау да организмнан кальцийны юдыра*. Кызыл таң

5) *куч.* Оныттыру, хәтердән җуйдыру. *Әмма тормыш тукталып тормый, үзенекен итә: ни авыр хәсрәтләрне дә юдыра, кышкы кайгылар язын оныталалар, крестьянның кызу эш көннәре җитә.* Я.Зәнкиев

**Юдыра бару** Һәрберсен, булган берсен бер-бер артлы юдыру

**Юдыра башлау** Юдырырга керешү. *Болгарларда кул берлән ашый торган ашлар алдыннан кул юылуын сөйләп бетермәс борын, хезмәткәрләр кечкенә-кечкенә комганнар берлән куллар юдыра башлады*. Г.Исхакый

**Юдыра төшү** Тагын да бераз юдыру

**Юдырып алу** Тиз генә юдыру. *Банкага салыр алдыннан кайнар су белән юдырып алу да әйбәт, болай итсәң, кыярлар кетердәп тора торган була*. Әлмәт таңнары

**Юдырып җибәрү** Тиз генә бераз юдыру

**Юдырып кую** Алдан юдырып әзер тоту

**Юдырып тору** Һәрвакыт, гел юдыру. *[Җимеш агачларына] Суны мул сибү, яфракларын юдырып тору кирәк*. Кәеф ничек?

**Юдырып чыгу** Башыннан ахырга кадәр, һәрберсен юдыру. *Ул шулай табындагыларның һәммәсенең дә кулларын юдырып чыкты*... Н.Яһудин

**ЮЕШ** *с.* **1.** 1) Өстенә юка гына су яткан, өслеге сулы булган, чыланган. *Әнкәй чыгып киткәч, торып утырдым, юеш тәрәзәгә маңгаемны терәп, аның ишегалдыннан үтеп китүен күрергә тырыштым*. А.Гыйләҗев. *Бәлкем, юеш яфраклар шулай кояш нурларында ялтырыйлардыр.* А.Гадел

2) Суга батырып чылатылган, суга манчылган, үзенә су сеңдергән. *Аның [Галиулланың] юеш киемнәреннән идәнгә яңгыр тамчылары коела иде.* А.Алиш. *Битен юеш кулъяулык белән сөрткәндә, Әбүзәр аңына килде.* А.Тимергалин

3) Нык дымлы, су парлары белән аралашкан. *Кухнядан тәмле булып пәрәмәч исе агыла иде, форточканы ачтым – тыштан яман салкын, юеш һава ургылып керде.* А.Гыйләҗев. *Монда [урман куелыгында] үскән кыргый җиләк җирдә килеш чери; юеш черек исе килә*... А.Тимергалин

**2.** *и. мәгъ.* 1) Берәр нәрсәгә сеңгән дым, түгелгән су. *Күкнең сүрүе ертылгандай, җиргә эре-эре яңгыр тамчылары коелды. Аяклар юештә тайгач, туп сыман аска тәгәрәштек.* Н.Гыйматдинова. *Шәһәрбану үрмәкүч пәрәвезе сарган түшәмгә, юештән мүк каплаган стеналарга күз салды*. Т.Гарипова

2) *куч. эвф.* Һәртөрле сыек бүлендекләр. *Зәңгәр күзле, сары чәчле, алсу иренле сеңлесе Нәфисәне бик ярата ул. Аның елавын, борчылуын, әле менә юештә ятуын һич телә̆ми.* С.Поварисов. *Борыныннан юеше кипмәгән, ни дигән була, диде ул, төкереген йотайота.* Р.Рахман

**3**. *хәб. мәгъ.* Югары дымлылык, дым микъдары күп булу. *Һава, диңгезгә тыгып алгандай, дымлы вә юеш.* Г.Ибраһимов. *Әкерен генә вак салкын яңгыр сибәли, комлы юллар юеш.* А.Нәҗми

◊ **Юеш авыз(лы)** Үсеп, ныгып җитмәгән; тәҗрибәсез, яшь. *Нурислам абыеңны танымыйсыңмыни? Һәй, юеш авыз!* Г.Әпсәләмов. **Юеш аяк** *эвф.* Ышанычсыз, таянырга, ярдәм күтәргә мөмкин булмаган кеше; зимагур, сукбай. *Таба да каба торган бу юеш аяклар тирәсендә бер дә акча төшереп булмаганлыктан, Сәфәргали аларны ташлап китеп барды.* Ф.Хөсни. **Юеш борын(лы)** *к.* **юеш авыз(лы)**. *Авыл арасында «чиккән яулык» дигән сүз таратканнар икән... Нәсимә юеш борын берәрсеннән ишетеп калып сайрый аны.* А.Гыйләҗев. **Юешкә утырту** Алдау, мәкер белән өстен чыгу. *Алпар егетенең мәкер, хәйлә, хәтта хәрәмләү исәбенә безнекеләрне юешкә утыртуын күреп, [Ярулла] кулындагы ачкычларын бер иргә тоттыра да мәйданга чыга.* Т.Галиуллин. **Юешкә утыру** Өмете акланмау, алдану; юкка тырышып йөреп, көлке, аяныч хәлдә калу. *Кызыгып алтын-көмешкә, Керештек без юк эшкә: Союзникларга сатылып, Утырдык без юешкә.* Г.Камал. **Юеш танау(лы)** *к.* **юеш авыз(лы)**. *Ул ярсуыннан буылып борылып караса, орчык кадәр ике юеш танау авызларын ерып торалар.* А.Гыйләҗев

**ЮЕШЛӘНДЕРҮ** *ф. йөкл. юн. к.* **юешләнү**. *Салкын су миңа рәхәтлек бирми. Күлмәкләремне юешләндереп, чиркандырып, тәнемә үтә.* Р.Рахман

**ЮЕШЛӘНҮ** *ф.* 1) Чылану, суга манчылу. *Чөнки беләсең, бу гадәт – Борынгыдан калган йола: Баштанаяк юешләнеп, Табигатьтән яңгыр сора!* Ш.Маннапов. *Аның чабаталарына кар тулган, киндер чалбар балаклары, башта җепшек кар белән юешләнеп, юлга чыккач катканнар.* Н.Яһудин

2) Юешкә әйләнү, дым сеңү. *Кышкы көннәрдә кайнар кер суы парыннан тәрәзәләр елый, чатлыклар юешләнә.* А.Шамов

**Юешләнә бару** Торган саен ныграк юешләнү. – *Каян алдың?* – *диде ул, һаман ныграк юешләнә барган борынын ике мәртәбә пыршылдатып*. Ф.Садриев

**Юешләнә башлау** Юешләнергә тотыну. *Әмма, балалар белән, мичне якмый торырга ярамый, юкса аларның гына түгел, минем дә борын астым юешләнә башлый, мин карлыгып сөйләшергә керешәм.* Т.Нурмөхәммәтов

**Юешләнә төшү** Бераз юешләнү

**Юешләнеп бетү** Бик нык, үтәли юешләнү. *Шулай уйнап-шаярып, ярга йөгереп чыктылар да, ах-ух килеп, көлешә-көлешә, юешләнеп беткән күлмәкләрен якындагы куакка элеп куйдылар*... Г.Гыйльманов

**Юешләнеп йөрү** Озак вакыт дәвамында юештә булу. *Тик барыбер, яңгыр яуганда, урамда юешләнеп йөрмисең бит инде.* Шәһри Чаллы

**Юешләнеп калу** Нинди дә булса сәбәптән соң юешкә әйләнү. – *Сер булса да әйтим, хан,* – *диде Визигаст король, юешләнеп калган мыегын кул аркасы белән сөртеп.* М.Хәбибуллин

**Юешләнеп китү** Бераз, берникадәр юешләнү. *Аяк асты да юешләнеп китте, баскан саен лычкылдап су чыкты.* Ф.Бәйрәмова

**Юешләнеп кую** Кинәт юешләнү

**Юешләнеп тору** Һәрвакыт, гел юеш булу. *Ансыз да калын, итләч һәм һәрвакытта да юешләнеп торган иреннәре җете кызыл булып янып тора.* М.Хәсәнов

**Юешләнеп чыгу** Кинәт кенә тоташ юешләнү. *Йөгерә торгач, картның хәле бетә башлады, күз аллары кинәт кенә караңгыланып китте, аркасы юешләнеп чыкты.* Ф.Бәйрәмова

**ЮЕШЛӘТҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **юешләү**. *Бөтен лифтны юешләтте бит тәрбиясез маэмае*... Ф.Җамалетдинова

2) Юешләү, су белән чылату, юеш итү. *Тәрәзәдән кинәт-кинәт исеп алган җәйге җил --- әле яңа гына яңгыр юешләтеп киткән юкәнең хуш исен алып*

*кирә...* Г.Хәиров. *Ислам динен тотучы татарларда да шулай ук кашык белән су салу, эчә алмаса, иреннәрен юешләтү бар – тиеш санала.* Безнең гәҗит

3) Юешләндерү, юешкә әйләндерү, су сеңдерү. *Ярый ла барысы да уң гына барса, яңгыры явып китеп, печәнне юешләтеп, черетә башламаса?* Ф.Яхин

**Юешләтә бару** Торган саен ныграк юешләтү. *Көзнең урталары булганга, төннәрен суытып, көндезен эретеп юешләтә барды.* Татарстан яшьләре

**Юешләтә башлау** Юешләтергә тотыну. *Өстән явып торган яңгыр да, алдан кисәтеп куйгандай, уеннар башланыр алдыннан туктады да, бәйгеләр төгәлләнеп, командалар кайтыр юлга чыккач кына, кабат бар дөньяны юешләтә башлады.* Шәһри Чаллы

**Юешләтә төшү** Тагын да бераз юешләтү

**Юешләтеп алу** Бераз, аз гына, кыска вакытка юешләтү. *Азатын искә төшереп, бер-ике мәртәбә күз төпләрен юешләтеп алды.* Н.Фәттах

**Юешләтеп бетерү** Тәмам, бик нык юешләтү. *Өскә менеп җитүгә, чиләк янтаеп түгелеп китә – бөтен тирәюньне юешләтеп бетерә.* Г.Гыйльманов

**Юешләтеп җибәрү** Бераз, аз гына юешләтү. *Иртәнге чык тирә-якны юешләтеп җибәргән*

**Юешләтеп калдыру** Юеш итү, юеш хәлгә китерү. *Быелгы язның беренче төнге яңгыры авыл йортларын, --- ялгыз ак каенны каралтып, юешләтеп калдырган.* Ә.Гаффар

**Юешләтеп кую** Алдан юешләткән булу. *Ятып торган җиремнән торып кухняга чапкан идем, улыбыз юешләтеп куйган җиргә таеп егылдым.* Акчарлак

**Юешләтеп чыгу** Һәрберсен бер-бер артлы юешләтү

**ЮЕШЛӘ́Ү** *ф.* 1) Махсус рәвештә чылату, юеш хәлгә китерү. *Тире юешләү чаннары идән уртасында калкытып эшләнгән.* А.Алиш. *Аның [Хәкимулланың] маңгаена юешләп сөлге япканнар.* М.Мәһдиев

2) Юешләндерү, юешлекнең сәбәбе, чыганагы булу. *Аның күз яшьләре битемне юешли.* А.Һадиев

3) Кече йомышны үтәү. *Ерткыч җәнлекләр арасында бердәнбер бүре кавеме шундый: үзенә тиң дошманын җиңгәч, бугазлап ташламый, өстенә менеп, юешләп мыскыллый да исән калдырып китеп бара.* М.Галиев

**Юешләп алу** Тиз генә, бераз юешләү. *Нәрсә моңаеп утырасың, сиңа да башыңны юешләп алу зыян итмәс!* З.Мәхмүди

**Юешләп бетерү** Тәмам, бик нык юешләү. *Тавышсыз гына аккан ул юеш тамчылар дүрнәемнең зәңгәр яулыгын чылатып, юешләп бетерде.* А.Әхмәтгалиева

**Юешләп җибәрү** Бераз гына юешләү. *Камырны аерып алганда, кулыңны юешләп җибәр*

**Юешләп тору** 1) Бертуктаусыз, гел юешләү. *Куе томаннар ел әйләнәсендә һаваны юешләп тора.* М.Гали

2) Әле, хәзерге вакытта юешләү. *Әни кеше аның иреннәрен генә юешләп тора.* Кызыл таң

**Юешләп чыгу** Тулаем, башыннан ахырына кадәр юешләү; һәрберсен, бер-бер артлы юешләү. *Шушы катнашма белән, алдан тузан суырткыч белән чистартылган келәмне җиңелчә юешләп чыгасы.* Шәһри Чаллы

**Юешли бару** Һәрберсен, булган берсен юешләү

**Юешли башлау** Юешләргә тотыну

**Юешли төшү** Тагын да бераз юешләү

**ЮЕШЛӘЧ** *и. зоол. диал. к.* **кыргаяк**

**ЮЕШЛЕ** *с. сир.* Юешли, юешләндерә торган; юеше булган, юештән торган. *Ун ел эчендә баштанаяк иренә ышануга, инануга баткан, чумган Нәфисәдә, --- сары кәфен киенгән көзге урман эчендәге шул юешле, суыклы көзге җил аның күңелендә иренә каршы беренче мәртәбә шөбһә уятты.* Г.Исхакый

**ЮЕШЛЕК** *и.* 1) Юеш булу сыйфаты, хәле. *Караңгы кич, аяк астындагы юешлек вә көчәйгән яңгыр – һәммәсе менләнең өметсезлеген арттырып, күңеленә бер кәефсезлек китерәдер иде.* М.Акъегет. *Очы юк юешлек тәнне баса, албасты пәрисе баскан кебек изә иде.* Г.Исхакый

2) *сөйл.* Дымлылык, дым микъдары. *Биткә сыек кына юешлек сугылды, борынга су исе, юеш исе бәрелде.* Г.Исхакый. *Һавада йөзгән бу юешлек безнең өстебезгә сеңеп бетте, землянканың бөтен бүрәнәләренә сарылды, хәтта ашый торган азыкларыбызга үтеп керде.* Ә.Еники

3) Юеш урын, юеш тирәлек, юеш әйбер. *Ә бит аңа, эссе коры яктан шушы салкын юешлеккә килеп эләккән кешегә, күптән авырып егылу кирәк иде.* Ә.Еники. *Кышын алтмышар градуска җиткән салкынлыкта, җәен озынборынлы, черкиле юешлектә эшләргә күнегү җиңел түгел.* С.Шакир

**ЮК** *хәб. сүз* **1.** 1) Нәрсәнең яки кемнең дә булса булмаганлыгын, чынбарлыкта очрамавын белдерә; *киресе:* **бар**. *Анда бернинди канал-арыклар да, яшел-зәңгәр урманнар да юк.* А.Тимергалин. *Кулы белгән кешеләр юк инде хәзер, менә элегрәк бар иде алар.* Ф.Яхин

2) Алда бирелгән сорауга тискәре җавап бирү, билгеле сүзне кире кагу, аның башкача булуын белдерү өчен кулланыла. *Ә Феникс алламы, түгелме? Юк, аның аллалыгы бик чамалы, утта янгач, яңадан терелә торган кош бугай ул...* А.Тимергалин

3) Икенче инкяр формасы белән бергә килеп, күрсәтелгән әйбернең, хәлвакыйганың очравын, булуын раслый. *Юк түгел аю, бүре, төлке – җиһан корткыч та бар.* Г.Тукай. *Озакламыйча, шәһәрнең беренче ахуны булу ихтималы да юк түгел.* Г.Ибраһимов

4) Тартым кушымчалы сүзләрдән соң килгәндә, әйтелгән кешенең яки әйбернең күрсәтелгән нәрсәсе, кешесе булмауны белдерә. *[Аның] Елап озатыр кешесе юк...* А.Тимергалин. *Шундый җырың юк икән, җаныңның кыйбласы, бәхетеңнең таҗы, сагышыңның даруы да юк, дигән сүз!* Ф.Яхин // Нинди дә булса сыйфаттан мәхрүм. *Адәм заты яшәмәгән йортның яме юк, диләр.* Г.Гыйльманов. *Сакалы биленә җиткән – акылы юк.* З.Мурсиев

5) Берәр эш-хәл, күренеш яисә вакыйганың билгеле шартларда була алмавын яки бөтенләй мөмкин түгеллеген катгый раслау өчен кулланыла. *Аллаһы Тәгаләнең бирмешеннән узмыш юк, дип киңәштеләр дә ни килсә – шуңа буйсынырга булдылар.* Ф.Яхин. *Ни дип әйтсен: кем әйтмешли, туры сүзгә җавап юк.* И.Диндаров

6) Берәр әйбернең бик шәп, бик көчле, бик әйбәт, уңай, күп яки, киресенчә, бик начар, кире сыйфатлы булуын тәгъбирләгән махсус әйләнмәләр (җөмләләр) төзү өчен кулланыла. *Ата-ана өчен баласының үз күңеленә хуш килә торган шөгыль табуын, шуның белән мавыгып, уңышларга ирешүен күрүдән дә олы шатлык юк.* Г.Галимуллина. *Болыннарда юа, кузгалак, чия, күгән, җиләкнең исәбе-хисабы юк.* Ә.Хәсәнов

7) Көтелгән нәрсәнең булмавын, теләгән эш-хәлнең гамәлгә ашмавын

белдерә. *Әнвәрдән өзелеп көткән хатлар һаман юк иде.* Ә.Хәсәнов. *Айга якын, бәлки, аннан да озаграктыр, вакыт үтте, җавап һаман юк.* Ә.Әминев

8) Сорау, үтенү яки өмет белән әйтелгән җөмләгә кире җавап җөмлә булып килә; *киресе:* **әйе**. – *Ә исемем минем – Рух. Шундый исемне ишеткәнең бар идеме? – Юк.* Г.Гыйльманов. – *Әллә еладыңмы? – Юк, күзгә чүп кенә керде.* А.Галиева

9) Кире эш-хәлгә, җавапка үкенүне белдерә. *Акчам булса, шәт, алган да булыр идем... Юк бит, юк...* М.Галәү. *Сөеп үстергән балалар аеруча миһербанлы, ярдәмчел булырга тиеш иде юкса, үгидәй күргәннәре аны сөймәс булып, аңа каршы астыртын хыянәт кылырга тиеш иде кебек. Юк бит, ул уйлаганча булмады.* Р.Батулла

10) Икеле, ышанычсыз яки ничек булса да барыбер булган хәлләрне белдергәндә кулланыла. *Юк бернәрсә дә, ди, күзен дә йоммый инде. Менә ышансаң ышан, ышанмасаң – юк.* З.Зәйнуллин. *Сыерчыклар --- бәләкәй өйләренә кереп-чыгып йөриләр, --- үзләренчә сырланган булалар: янәсе, ошап бетәр микән, юк микән.* Р.Кәрами

11) Җөмләдә куелган сорауны, катгый таләпне яки өметләнүне, шик-шөбһә, икеләнү, аптырауны көчәйтеп яки ассызыклап сорау формасында әйтелә. *Антонов бик җитди итеп, тик әйтимме икән, юкмы икән дигәндәй, дусты Василевскийга икеләнеп карады.* З.Зәйнуллин. *Сабира апа, син безгә бүген чәй эчерәсеңме соң, юкмы?* Р.Сәгъди

12) Синонимнар яки бер даирәдәге төшенчәләрне белдергән сүзләрдән соң килгәндә яки кабатланып әйтелгәндә, сукранып шелтәләүне аңлата. *Яңа кешеләр килгәннән бирле ашаган юк, эчкән юк, юньләп йоклаган юк: эш тә эш...* Т.Гыйззәт. *Ни кибете, ни мәктәбе, ни юлы юк.* Я.Шәфыйков

13) Вакытны, мизгелне һ.б. белдергән сүзләрдән соң кабатланып, берәр эш-хәлнең даимилеген, туктаусыз дәвам итүен белдерә. *Шахтёр – Җир шарының корты; аңа көн юк, төн юк, – казый, тишә, җирнең эченә керә...* Ш.Камал

14) Исем фигыль белән белдерелгән мәгънәне инкяр итү өчен кулланыла. *Әмма председательне күрми китү юк.* Т.Гыйззәт. *Өйдә каршы сөйләү юк, малайлар балачактан шулай тәрбияләнгән.* З.Кадыйрова

15) Катгый таләп итү мәгънәсендә кулланыла. *Артка чигенү юк, барысы да ачыкланыр, барысы да тәртипкә керер.* З.Хәким. *Тәртип нык булсын, төзелештән читкә китеп йөрү юк.* Н.Акмал

16) Сыйфат фигыльдә күрсәтелгән эш-хәрәкәт, гамәлнең һ.б.ш.ның бервакытта да булмавын белдерә. *Хисмәт бабайның гомерендә кеше нәрсәсенә тигәне юк.* Т.Гыйззәт. *Бер дә атка атланган юк әле минем...* В.Гали

17) Хәл фигыльнең -*асы*/-*әсе*, -*ыйсы*/-*исе* формасы белән белдерелгән эш-хәрәкәтне, теләкне, сыйфатны һ.б. инкяр итү өчен кулланыла. *Яшьли сөйгән сөеклесен Онытасы юк, үлмичә.* Х.Туфан. *Буадагы балыкның бетәсе юк.* А.Тимергалин

**2.** *и. мәгъ.* 1) Үзендә булмаган нәрсә, булдырырга тырышкан әйбер. *Дөнья көткән кешегә һәрвакыт нәрсә дә булса җитми. Әнә шул юкны булдыру өчен яшибез түгелме соң?* З.Мурсиев

2) Бик әһәмиятсез нәрсә, вак-төяк. *Юктан күңелеңне бозма.* Ф.Яхин. *Башыңны юк белән катырмыйм, дигән идем.* Н.Гыйматдинова

3) Ярлы, фәкыйрь кеше. *Бай белән дә баемассың, юк белән дә югалмассың.* Мәкаль

**3.** *мод. сүз функ.* 1) Берәр фикергә, фаразга яки омтылышка карата инкяр итү белдерелгән җөмләдә мәгънәне көчәйтеп килә. *Юк, юк, тәкәбберлекнең тамчысы да юк иде аңарда.* Г.Гыйльманов. *Юк, бармыйча ярамый, мин бит сүз бирдем.* Аманулла

2) Кискен чик кую яки соңгы чиккә җитүне белдерә. *Чал чәчле карт сугышчы, --- бәлки, бугазны киеребрәк кычкырырга бу очракта аның хакы да булгандыр, ләкин юк, кычкырмады.* Ф.Хөсни. *Ничек бу тискәре кызны сындырырга? Юк, сындырырга түгел, иптәргә, имләргә, күңеленә дөрес оетки салырга, музыканы йөрәге белән тыңларга өйрәтергә?* З.Мурсиев

**4.** *с. мәгъ.* 1) Булмаган, чынбарлыкта яшәве төгәл билгеле түгел; булмый торган, тормышка ашмаслык. *Ә юк әйбер сүрелә дә, сүнә дә алмый.* М.Кәбиров. *Арыган ми галәмәте булып, эңгермеңгердә юк нәрсәнең дә күзгә күренүе ихтимал лабаса.* Р.Батулла

2) Әһәмияте булмаган, кирәкмәгән, буш, начар. *«Күп сүз – юк сүз» ди бит татар да.* А.Тимергалин

3) Җәнҗаллы, ызгышлы, гаугалы. *Маташма, җаным, юк эш белән!* З.Мәхмүди. *Юк эшкә кердегез, юк эшкә!..* К.Тинчурин

4) Җәмгыятьтә зур урын тотмаган, түбән дәрәҗәдәге; корыга мактанып, күп буш сүз сөйләүчән. *Әгәр берәү, зурдан кубып, мин фәлән-төгәнне беләм, без бергә аның белән... дип сүз башласа, аны тыңламау хәерле, чөнки ул – юк кеше.* К.Сатиев

5) Таныш түгел, үз булмаган, чит, ят; булуы билгесез. *Фәтхи беркем дә түгел миңа, ул – минем өчен юк кеше.* Х.Мөдәррисова

**5.** *терк. мәгъ. Ә, әмма, ләкин* кебек сүзләрне алмаштырып, фикерне кискен каршы кую өчен кулланыла. *Ләйлә белән өстәл әзерлим, дип качмакчы гына булам, юк, җибәрмиләр, сез – кунак, без үзебез эшлибез, диләр.* А.Галиева. *Кояш күтәрелде, юк, томанны тарата алмады*

◊ **Югы аяктан ега** «Мал, акча булмау, мөмкинлекләрнең чикле булуы интектерә» дигән мәгънәдә. **Югы муенны кисә** *к.* **югы аяктан ега**. **Югын бар итеп** Ничек тә мөмкинлек табып, хөрмәт итәргә тырышып. **Юк бәя** Бик арзан хак. *Аның чыгымнары күп, юк бәя белән арадашчыларга, алыпсатучыларга сатып җибәрү файдага түгел.* Безнең гәҗит. **Юк вакытын бар итеп** Эше тыгыз булуга карамастан, ничек тә вакыт табып. *Юк вакытын бар итеп, карчык янына Исмәгыйль дә кагылып чыга.* Ә.Сафиуллин. **Юк дигәндә** 1) Иң аз, бик аз дип уйлаганда, ким дигәндә. *Кара көннәр килсә, кемнәрнеңдер, Юк дигәндә, уты-шәме бар.* Р.Шәрипов; 2) Һич югы, бер дә булмаса. *Күбесе тамакны бакчага салганнар: күпләп бәрәңге утырталар, кишерен, шалканын, кәбестәсен дигәндәй, өзепйолкып булса да берәр бозау үстерергә тырышалар, юк дигәндә тактадан урын әмәлләп, әтәч-тавык карыйлар.* К.Кара. **Юк елгага юк тегермән** Юкны бар итеп сөйләү, булмас хыялларга бирелү. *Юк елгага юк тегермән корып йөрмисеңме, дим.* Ә.Хәсәнов. **Юк җирдән** 1) Уйламаганда, һич көтмәгәндә, кинәт. *Бала аларга бәхет китерде, юк җирдән нурлар иңдерде.* А.Нәҗми; 2) *к.* **юк өчен**. *Ул үзе юк җирдән бәйләнә һәрвакыт.* Р.Гаязетдин. **Юк инде** Кискен каршы төшүне, катгый инкярны белдерә. *Юк инде, шушындый табигатьтән үзе теләп кем баш тартсын!* Н.Кәримова. **Юк йомышны бар итеп** Юри сылтау табып.

*Мансур кайткannan соң, Илһамия, юк йомышны бар итеп, Таһировларга бик еш йөри башлады.* Г.Әпсәләмов. **Юкка без дә тук** «Юк» дигән җавапка ризасызлык белдереп әйтелә. **Юкка исәп** Бик аз күләмдә, юк дәрәҗәсенә якынайган, юк сандагы. **Юкка калган** Бөлгән, бөлгенлеккә, фәкыйрьлеккә төшкән. *Үзгәртеп кору бара бит, үзебездә дә хәлләр әйбәтләнә бара, юкка калган, дип уйлаган идем.* Р.Миңнуллин. **Юкка чыгару** 1) Бетерү, юк итү. *Мин, Булат белән икебезнең арада туган киеренкелекне тизрәк юкка чыгарырга теләп, сүз башларга ашыктым.* Г.Гыйльманов; 2) Юкка чыккан дип исәпләү, юкка чыкты дип уйлау. *Без, парин, сине бөтенләй юкка чыгарган идек бит, әй.* Г.Минский; 3) Кемнең яки нәрсәнең дә булса яхшы атын, данын, сүзен, фикерен инкяр итү. *Вакыт-вакыт --- Газдал Кәукәбелҗәннәткә төртмә сүз әйтә, гел кирегә сукалый, аның сүзен юкка чыгарырга тырыша.* Ф.Садриев. *Ә Мотаһирны хуплаучылар, кешенең кешелеген генә түгел, исем-фамилиясен дә юкка чыгарырга тырышалар икән, моңа мөмкин хәтле каршы торырга кирәк, диделәр.* Р.Кәрами. **Юкка чыгу** 1) Кинәт югалу, күренмәү. *Портфель юкка чыккан, ноутбуктан да җилләр искән!* Ф.Бәллүр; 2) Бетү, юк булу; кирәге калмау. *Киртәнең бу ягына [зиратка] утү белән матдилекнең, өстенлекләрнең кирәге юкка чыкты.* М.Юныс. *Тик аның маңгаендагы күк тамга – Тәңре билгесе генә юкка чыккан.* Г.Гыйльманов; 3) Яшәүдән туктау, һәлак булу. *Авылның иң батыр ирләре сугышта юкка чыккан.* **Юк кына** Бик вак, әһәмиятсез, көчсез. *Кысыр алмагач – Калтырый юк кына Җил килеп какса да.* З.Мансур. **Юкны бар итеп** Аз мөмкинлекләрдән чыгып, булдыра алганча. *«Бу иске йортымны сүтәргә кулым күтәрелми, авыр елларда, юкны бар итеп, үзем салып чыктым лабаса», – дип, гел сөйләнә иде мәрхүм.* Г.Габидуллина. **Юкны бар итү** 1) Булдыру, барлыкка китерү. *Барына риза булып, юкны бар итәргә тырышып йөргән эш аты иде ул.* Ә.Әминев. *Тормышның бар кызыгы да шунда: юкны бар итәргә тырышып, булганның бәрәкәтен тоеп яшәүдәдер.* Ф.Мөслимова; 2) Бөтенләй өметсез, булмаслык шартларда да мөмкинлек, җай табу. *Юкны бар итеп, өзеп-йолкып дигәндәй, кызын укытырга тырышты ул.* К.Кара; 3) Берәр сылтау табу, юк сәбәпне бар итү. *Юкны бар итеп, Айбикә инәйгә кереп чыкты.* З.Кадырова. **Юкны бушка бушату** Мәгънәсез эш белән шөгыльләнү; буш сүз сөйләү. *Халык чын йөрәктән сөйләшүне, мәсьәләне уртага салып, ышанып киңәшкәнне ярата, акыл сатканны, юкны бушка бушатканны өнәми ул.* Г.Әпсәләмов. **Юкны туглау** Юк-бар эш белән йөрү. *Сүзегезне бүлдем бугай ла мин, Гафур абый! Йөрим шунда юкны туглап...* А.Гыйләҗев. **Юк өчен** Бер дә кирәкмәгәнгә, урынсызга. *Берлин ерак әле, сугышырга өлгерерсең, кайгырма юк өчен...* С.Поварисов. *– Үз башына төшкәч, барысын да булдырыр әле, юк өчен кайгырмагыз, – диде Гөлшәһидә.* Г.Әпсәләмов. **Юк сүз** Имеш-мимеш, асылы булмаган, буш сүз. *– Иң кирәклесен сөйләшмәгәч, нигә юк сүз белән авыз пычратырга! – дип кызып китә Исхак.* А.Гыйләҗев. **Юктан барга исәп** Мохтаҗлыктан, юклыктан гына берәр нәрсә исәптә-санда йөрү, әлегә ярап тору. **Юктан гына кодагый** 1) *этн.* Үз әнисе булмаган, ятим үскән кияүнең туйда әнисе ролен үтәүче кеше; 2) Бик түбән сыйфатлы, үз дәрәҗәсенә, исеменә лаек булмаган шәхес яки әйбер. **Юктан юкамыш пешерү** 1) Нигезсез өметкә бирелү; 2) Сәбәпсез ызгыш-талаш, гауга, шау-шу чыгару, җәнҗаллашу. **Юк түгел** Берәр нәрсәнең барлыгына, булуына, урын тотуына киная белән әйткәндә кулланыла; бар, күзәтелә, урын алган. *Мулла бабай дөрес, яхшы күңелле, эчкерсез кеше булса да, аның киреләнә торган гадәте дә юк түгел.* С.Поварисов. **Юк эшне бар итеп** Берәр сылтау табып. *Түбән Камага, юк эшне бар итеп, ничә мәртәбә генә баргандыр.* Ф.Садриев. **Юк янында** Бар белән юк арасында, юк диярлек, аз гына. *Чәчүлеккә дигән бәрәңгеләре юк янында иде*

**ЮКА** I *с.* **1.** 1) Яссы әйбернең аркылы кисеме кечкенә, нечкә булган; киресе: **калын**. *Ләкин рәхәт көннәр озакка сузылмады: зәһәр салкыннар китереп бәрде, тирә-юнь юка кар катламына төренде.* В.Имамов. *Стеналар пөхтә итеп юка такта белән тышланган һәм, бик шәпләп, олиф белән буялган.* А.Гыймадиев

2) Куе түгел, сирәк. *Кояшны каршы алырга офык артыннан чыккан юка, чуар болытлар алсу нурга манчылдылар.* А.Гыйләҗев. *Кап-кара кашларына төшеп торган юка ак чәчләре исә бөтенләй балаларча самимилек өсти иде.* А.Әхмәтгалиева

3) Салкын үткәрә, салкыннан саклый алмый торган, җылы түгел, җиңел. *Әле мин белгәндә генә Сираҗи кышкы сукта бер кат юка бишмәт белән калтырап туңып йөри торган бер кибетче малай иде.* Г.Камал. *Өстендә култык астындагы тишекләреннән көзге яңгырлы ачы суык җил уйнап торган юка пальто.* Г.Ибраһимов

4) Какча гәүдәле, нәзек, ябык, чандыр. *Тәнзилә бала вакытта елак кына, усал гына, нечкә сыйраклы, юка гәүдәле бер кызчык иде.* А.Гыйләҗев

5) Итләч булмаган, нечкә. *Ул, әледән-әле җиң очын тарткалап, чыра шикелле юка беләкләрен яшерергә тырыша иде.* Г.Бәширов. *Теге [шофёр], күзләрен акайтып, бер Азатка, бер тимер сыныгына карый, агарынган юка усал иреннәре калтырый башлый.* А.Тимергалин

6) Нечкә һәм яңгыравыклы, югары. *Балалар Гарәф абыйларының шаяртуларына күнегеп бетkәннәр иде, аның юка тавыш белән чәрелдәвенә, көлешә-көлешә, ишеккә ташландылар.* Ф.Сафин

7) *күч.* Аз, нәтиҗәле түгел, сыек, фәкыйрь. *Нигә соң синең ындырдагы Эшең бик юка?* М.Җәлил

8) *күч. сир.* Көчсез, чыдамсыз, егәрсез, хәлсез. *Әллә буын яшькә күкрәк юка, әллә куллар ныгып җитмәгән.* Ш.Маннур

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Нечкә итеп. *[Табынга] Бик юка туралган, борчак оны катыш арыш оныннан иләмичә пешерелгән, уалып торган ипи килде.* А.Гыйләҗев

2) Җиңелчә генә, калын киемнән түгел. *Шәһәрчә юка киенгән кыз тукталышта бик озак автобус көтте.* Г.Мирһади

**ЮКА** II *и. к.* **юкамыш**. *Тукта, буңар карап торырга ярамас, ичмасам, ак оннан бераз күмәч кабартып куйыйм, өч-дүрт йомыркадан гына булса да кош теле, юка пешереп алыйм.* Г.Исхакый

**ЮКАБАШ** *и. сөйл.* Акылсыз кеше. *Их, мин әйтәм, юкабаш! Ярминкәдән кайтмый торганыңа дөмеккән идең инде син, әле ярый мин булдым.* Г.Бәширов

**ЮКАГАЧ** *и.* **1.** Кайрысы суелган юкәнең үзагачы. *[Картәтәй:] Бик бирештем быел, улым! Юкагач ташуы авырайды. Бер барганда биш-алтыдан ары күтәреп булмый.* Н.Фәттах

**2.** *с. мәгъ.* Шундый үзагачтан эшләнгән. *Фазулла бабай белән әбисе балчык белән катырган бәләкәй генә юкагач өйләрендә икәүдән-икәү генә торып калдылар.* З.Зәйнуллин

◊ **Юкагачка атландыру** Төрле ялган вәгъдәләр белән нәрсәне дә булса алдап алу

**ЮКАЛЫК** *и.* 1) Юка булу дәрәҗәсе. *Шул ук озынча ак бит, атасыныкы төсле калын кашлар, тынгысыз коңгырт күзләр, шул ук чандырлык, юкалык.* Н.Фәттах

2) Фәкыйрьлек, ярлылык. *Хуҗа, табынының юкалыгыннан читенсенеп, күзләрен түбәнгә төшереп тирән генә бер көрсенде.* А.Гыйләҗев

**ЮКАМЫШ** *и.* Юка гына җәеп табада пешерелгән камыр ризыгы; табикмәк

**ЮКАРУ** *ф.* 1) Калынлыгы кимү, юка булып китү, юкага әйләнү, нечкәрү. *Күкерт кислотасы бакырны эретәдер, аннан тагы бакыр куфараз пәйда буладыр, шул сәбәпле бу кулланууда бакыр кисәге дигәнебез кими вә юкара.* К.Насыйри

2) Сирәкләнү, тыгызлыгы, куелыгы кимү. *Агыйдел өстендәге төн пәрдәсе юкара.* Г.Гобәй

3) *күч.* Ябыгу. *Аның нечкә гәүдәсе дә, бугаз төере алга чыгып торган озын муены да, иләмсез озын борыны да, ничектер, барысы да юкарганнар.* Г.Әпсәләмов

**Юкара бару** Акрынлап, аз-азлап юкару; торган саен күбрәк юкару. *Берсенең кесәсе калынайган саен, икенчесенеке юкара бара.* В.Гали

**Юкара башлау** Юкарырга тотыну, юкару билгеләре күренү. *– Юл төшләре күрмәгәниеңме, Майшәкәр апа? – диде председатель, юкара башлаган чәчен артка тарый-тарый. – Юлга апчыгарга дип килдем бит әле мин сине.* Сөембикә

**Юкара төшү** Бераз юкару. *Гали абзыйның болай да чандыр йөзе тагын да боеккан, кылыч борыны да юкара төшкән.* Г.Әпсәләмов

**Юкарып алу** Азга, кыска вакытка гына юкару. --- *сүз башына кайтыйк, дигәндәй, – юкса [сүз] җебе юкарып алды, гафу үтенәм.* Ф.Яхин

**Юкарып бетү** Тәмам, бик нык юкару. *Мамык шәл инде тузган, юкарып беткән.* Г.Әдһәмова

**Юкарып калу** Берәр төрле сәбәптән, вакыттан соң юкару; бөтенләй юкару. *Бурычларны тапшыргач, [кесә] бөтенләй юкарып кала.* Ф.Бурнаш. *Болай да ябык, сузан кеше, ул хәзер бөтенләй юкарып калган.* А.Расих

**Юкарып килү** Акрынлап юкару. *Игътибар: таҗ төбенә гипс калынрак ягыла, очына таба юкарып килә.* Сөембикә

**Юкарып китү** *к.* **юкара төшү**. *Чырае көл төсенә кергән, тыгыз калын ияге сыер карынына уайый шәлперәеп төшкән, хәтта тышау җитмәс муены да юкарып киткәндәй күренә.* М.Әмирханов

**ЮКӘ** *и.* **1.** 1) Мальвачалар семьялыгыннан кабыгыннан мунчала алына, үзагачы җиһаз ясау өчен, төзелеш материалы буларак кулланыла торган, саргылт вак хуш исле чәчәкле, йөрәксыман яфраклы агач. *Тирә-юне сыек яшел яфраклы юкә, каен агачлары белән ярымбоҗра сыман уратып алынган түгәрәк күл.* А.Вергазов. *Мәтрүшкәләр, юкә чәчәкләре кайнатып, шул төнәтмәләрне дә эчерә торгач, баланың хәле яхшыра төшкәндәй тоелды.* А.Әхмәтгалиева

2) Шул агачның кабыгы. *Ул юкә батырып мунчала суя, шуңардан пумала бәйлиләр, чыпта сугалар, тал кайрысы әзерләп тапшыралар.* З.Мурсиев

3) Чабата, кызау, тубал һ.б.ш. әйберләр үрү өчен, яшь юкә кабыгыннан телеп алынган тасма. *Аның [Вәли картның] сумкасында кайрак, пәке, юкәдән үргән чехол эчендә шешә белән су, шырпы, ашау ризыгы.* М.Мәһдиев

4) *сөйл.* Мунчала; юкәр. *Ишегалдында юкәдән бау ишеп маташкан Хәләф урыныннан куба алмыйча торды.* Ф.Яхин

**2.** *с. мәгъ.* 1) Шул агачтан ясалган, шуның үзагачыннан әзерләнгән. *Өч ел йөреп, күреп күнегелгән урыннар бөтен ваклыклары – су тамып торган юкә такта түшәмнәре, кыйшайган яңаклы ишекләре һәм саламнары бүселеп-бүселеп торган түбәләре белән күңелдә калыктылар.* А.Гыйләҗев. *Юкә бүрәнә мунча салырга бер дигән, ә кабыгын, кубарып, бакча артындагы күлгә батырдык.* Сөембикә

2) Шул агачның кабыгыннан ясалган. *Хуш исле юкә бишектә тибрәнеп үскән чагым... А.Хәлим*

3) Шул агачның кабыгыннан суелган тасмалардан үрелгән. *Сарык дисәң, сарыкка әллә ни охшамаган лабаса бу – әнә бит өстенә иске сырма киеп алган, башында колакчын бүрек, аягында юкә чабата...* Г.Гыйльманов. *Тугызак әби, тугыз улына тугыз юкә кызау биреп, урманга җибәрде.* Ф.Вәлиев

4) *сөйл.* Мунчаладан, юкәрдән ишелгән. *Кигәвен, черки вакыты булуга карамастан, шунда да [Баһадир (ат)] үзен бик сабыр тоткан иде: барлы-юклы юкә дилбегә-арканын ник бер тапкыр өзеп карасын, ичмаса!* В.Нуруллин. *Иске генә саргылт чикмәне өстеннән билен бозау муенчагы шикеллерәк юкә бау белән бәйләп куйган.* Н.Яһудин

◊ **Юкә белешмә** *к.* **юкә язу**. **Юкәдән ясалган** Начар, юньсез; булдыксыз, кулыннан эш килми торган (кеше тур.). *Юк, мин әйтәм, сандугачкаем, Фәрхетдин юкәдән ясалмаган.* Ш.Бикчурин. **Юкә урынына каезлау** Чамасыз талау, бик нык алдау. **Юкә чөй** Юха тел, юмалау сүзләре. *Әти сүзне авылча ерактан урап, профессорга юкә чөй кыстырып, баллап-шикәрләп әйтте.* Гөлшәһидә. **Юкә язу** Ялган язу, ялган белешмә

**ЮКӘЛӘ́Ү** *ф. сөйл.* 1) Алдаштыру, чынга ялган кушу. *Бер янына бишне юкәли бит ул*

2) Юмалау, җайлау, татлы сөйләү. *Әй, юкәлисең дә инде, каһәр.* Ш.Камал

**ЮКӘЛӘҮЧЕ** *и. сөйл.* Юмакай кеше. *Юкәләүченең теле татлы була*

**ЮКӘЛЕК** *и.* Күпләп юкә агачлары үскән урын, юкә урманы. *Бакча башыннан шау чәчәккә чумган юкәлек башлана.* Р.Мөхәммәдиев

**ЮКӘР** *и.* Агач яки кура кабыгының эчке, кайры астындагы сүсле катламы. *Кайры һәм бөке катламы агачны тышкы тәэсирдән һәм механик тәэсирдән саклый, ә юкәр аша органик матдәләр ябалдаштан агач кәүсәсенә һәм тамырга килә.* З.Камалова. *Кабыкның эчке катлавы юкәр дип атала, аның составына органик матдәләр, хәрәкәтләнә һәм сабакка ныклык бирә торган күзәнәкләр керә.* Биология

**Ю́К-БАР** *җый. и.* **1.** 1) Әһәмиятсез, кирәксез, мәгънәсез нәрсәләр. *Туктап, исәнлек-саулык сорашып, юк-бар сөйләшеп тордык...* Л.Ибраһим-Вәлиди. *Әй яшьлек, җыен юк-бар өчен янып-көеп йөрүләр...* И.Сираҗи

2) Ялган, уйдырма сүз, гайбәт, төрле имеш-мимеш һ.б.ш. нәрсәләр. *Ирем Наил дә бик әйбәт, мине аңлады, юкбар белән үртәмәде.* Яңарыш

3) Куркыта яки шатландыра торган, ләкин чынлыкта булмаган нәрсәләр: ырым, сихер, җен-өрәк, төш һ.б. шундыйлар. *Әйе ул аны [төшен]*

*Мотаһирга сөйләмәдә бит әле. Әллә юк-бар белән иренең башын катырмаска, кәефен кырмаскамы?* Р.Кәрами

**2.** *с. мәгъ.* 1) Әһәмиятсез, кирәксез, мәгънәсез. *Гаишник туктата, юк-бар сәбәп табып бәйләнә.* Ф.Дәүләтбаев

2) Ялган, уйдырма, асылы булмаган. *Мондый хәбәр таралса, эшлекле атмосфера калыр димә, юк-бар сүз – агачны эчтән ашап барган корт кебек ул.* М.Миншин

3) *к.* **юк 4.** (*3 мәгъ.*). *Синең юк-бар кеше генә түгел икәнең маңгаеңа язылган.* Н.Акмал

**Ю́К БУЛУ** *ф.* 1) Кинәт югалу, күренми башлау. *Тамчылар җиргә тәгәрәп төшеп юк була.* Р.Батулла. *Калган өч конвойчы да капка артында юк булды.* Р.Кәрами

2) Бетү, юкка чыгу. *Әмма, Кылый Хәмит исемен ишетү белән, Миңлегөл йөзендә туган шатлык-куаныч нурлары, җил тузгыткандай, шундук юк булды.* М.Хәсәнов

**Ю́К ИСӘ** *терк. к.* **югыйсә**. *Юк исә, сессия вакытында шактый гына күңелсезлекләр дә булырга мөмкин иде.* И.Кашфразыев

**Ю́К ИТҮ** *ф.* 1) Бетерү, юкка чыгару. *Сиңа мин бер адрес бирәм, аны минем алдымда ятла да, аннары кәгазьне юк итәрбез.* А.Тимергалин

2) Тиз генә яшерү, качыру. *Юк итәм хисләрем кәсәсен.* А.Имамиева

3) Үтерү, һәлак итү. *Минем өч абыемны юк иткәнсез бит сез!* З.Мәхмүди

**ЮККА** *рәв.* 1) Булмаганга, булмау сәбәпле, булмау нәтиҗәсендә. *Баягы газапларга сәбәп булганлыгы өчен кыйнап ташларга уйласа да, хәле юкка тукталды.* Г.Ибраһимов

2) Нигезсез, бер сәбәпсез, тиккә, тикмәгә, тиктомалга. *Маһруй апа, мин зур кешеләр белән сөйләшә белмим, дип юкка гына куркып йөргән икән.* Г.Әпсәләмов. *Вакытын юкка әрәм итмәде.* Т.Әйди

3) Инкяр итү яки юклык формасы белән берлектә нәрсәне дә булса раслау, ышандыру өчен кулланыла. *Күл ягыннан ах-ух килеп ишетелеп торган тавышларның кинәт туктап калуы да юкка түгел...* Г.Гыйльманов. *Аһ, юкка аларга өметләнәме? Аларның хәбәрен тыңлап, ару җан, юкка иңрәнмә!* А.Җәгъфәр

4) Мәгънәсезгә, бушка, кирәкмәгәнгә, нәтиҗәсезгә. *Бәйрәшеваның бүгенге мәкаләсе безгә аяк чалу өчен оештырылган, дип уйлыйм – юкка тырышалар! Без барыбер бирешмәячәкбез!* А.Тимергалин

5) Билгеле эш-хәлгә, вакыйгага һ.б.ш.га үкенү яки йомшак кына шелтәләү мәгънәсен белдерә. *Юкка ачуландым, юкка бәпкәемә карыштым...* А.Алиш. *Ананың күңелендә: «Нидер яшерә, юкка җибәргәнмен баланы, үзем генә барасым калган», – дигән уй кайнашты.* С.Поварисов

◊ **Юкка йөрү** Кирәкмәгән, файдасыз, булмастай эш артыннан йөрү. *Юкка йөрисез, сезнең алда тәүбә итәрлек гөнаһ эшләгәнем юк минем!* Г.Ибраһимов. **Юкка көл иләү** *к.* юкка йөрү

**ЮКЛА́У** *ф. сөйл.* 1) Кинәт күздән югалту

2) *к.* **юксыну** (*1 мәгъ.*). *Мине юклап сөйләрсез мәй телендә.* Г.Хәйям. *Бердәнбер таянычы – улы үтерелү хәбәрен ишеткәч, аның [карчык] теленнән әйтелгән юклау шигыре «Бүз егет» дастанында Баһави язган юклау җырына өлге, үрнәк булган булуы мөмкин.* М.Гайнетдин

**ЮКЛАУЧЫ** *и. сөйл.* Юксынган кеше. *Сине юклаучы юк иде*

**ЮКЛЫ́-БАРЛЫ** *с.* **1.** *к.* **барлы-юклы**. *Ул, кинәт терсәгенә таянып, юклы-барлы хәле белән торырга итенә башлый.* Г.Ахунов. *Акчасы юклы-барлы гына булса да, Фәгыйлә аны [Тукай әсәрләренең беренче зур җыентыгын] кулыннан бирмичә сатып алды.* С.Сабиров

**2.** *рәв. мәгъ.* Аз, күп түгел; начар. *Булдым ярлы, киендем юклы-барлы.* Г.Камал

**ЮКЛЫК** *и.* 1) Булмау, юк булу хәле. *Һәрбер гакылсызлыкның сәбәбе тәрбия юклык.* Г.Бубый. *Янымда таянычым юклык көннән-көн ныграк сиздерә.* Г.Гыйльманов

2) Ярлылык, фәкыйрьлек, мохтаҗлык. *– Әгәр минем белән барсаң, аны ачып, сиңа шулкадәр алтын бирермен – гомереңдә юклык күрмәссең, – диде.* К.Насыйри. *Их син, гүзәл һәм кыска гомерле яшьлек! Замана авырлыклары, юклык вә михнәте белән дә ул бәхетле һәм гомер буе сагынып сөйләрлек.* З.Мурсиев

3) *лингв.* Эш-хәрәкәтнең булуын инкяр итүне белдерә торган грамматик категория; *киресе:* **барлык**. *Фигыльне исемнән һәм башка сүз төркемнәреннән аера торган иң универсаль чара – аның юклык формасы.* Ф.Хисамова

◊ **Юклык заман** Ачлык, кытлык чоры. *Елар идем эчем пошканнан; Тик әнкәйләр юклык заманда ук Безгә еламаска кушканнар.* Р.Идиятуллин. **Юклыкка чыгу** *сир. к.* **юкка чыгу**. *Һавада берничә минут салынып, юклыкка чыга барган тәмәке төтене кебек, аның [Насрыйның] фикер-хыяллары да таралып китә иделәр.* Ш.Камал

**ЮКМЫШ** *и.* 1) Юк нәрсә, дөньяда булмаган әйбер

2) Фәкыйрьлек, кытлык чоры. *Тишек прощайлы «юкмыш» чорларыбыз артта калды.* Безнең гәҗит

◊ **Юкмыш бабай** Дөньяда булмаган, яшәмәгән бабай; Хәсән Туфанның «Юкмыш бабай малае» экиятеннән сөйләмдә активлашкан образ. *Балалар әдәбиятында Юкмыш бабай мәңге бар булмыш!* Ш.Галиев. **Юкмыш бабай заманында** Бервакытта да, һичкайчан. **Юкмыш буш акча** Юк акча; акча булмау, акчасызлык

**ЮКНЫ** *рәв. диал.* Юкка, файдасызга. *Йокы калдырып йөрмәгез юкны.* Ш.Камал

**Ю́КСА** *терк. к.* **югыйсә**. *Ярдәмгә килүегез өчен рәхмәт, кызлар, юкса карлыган белән алма коела башлады.* В.Имамов. *Әни аңар: – Карагыз, кала күрмәгез, юкса без сезсез китеп тә барырбыз, – диде.* А.Алиш. *Әллә берәр дәрвишме, юкса төн адашкан юлчымы?* Б.Мирзанов

**ЮКСЫЛ** *с.* **1.** Ярлы, фәкыйрь, мохтаҗ. *Әмма юксыл бәндәләренә Аллаһы Тәгалә хаҗ боермады.* К.Насыйри. *Без барлык олуг эшләрне авыр һәм юксыл дәверләрдә ерып чыктык.* З.Мурсиев

**2**. *и. мәгъ.* 1) Ярлы, хәерче, фәкыйрь кеше. *Колагымда фәкать юксыллар аһ-зары.* Ә.Үргәнчи. *Читкә кума син ятимне, узгынчыны, юксылларны, ал табынга...* Р.Батулла

2) Юксыну, озак күрми торудан сагынып борчылу халәте. *Авылдашларыгыз Касыйм белән Салисә Япониянең җылы җилләре аша һәммәгезгә юксыл тулы сәламнәр җибәреп, хәер-догаларыгызны өмет итеп кала.* В.Имамов

**ЮКСЫЛЛЫК** *и.* Юксыл булу хәле, фәкыйрьлек, ярлылык. *[Зиннәтулла мулла йортындагы] Бу гауганың төп сәбәбе, әлбәттә, юксыллык, балаларның тамагы ач, өсләре ялангач булудан килә иде.* Р.Батулла

**ЮКСЫНУ** *ф.* 1) Кемнеңдер юклыгыннан, нәрсәдер булмаудан сагынып пошыну, күрәсе килүдән авыр хисләр кичерү. *Әбүзәрнең үзе кебек үк бөтен авылда дан тоткан эте Бүретотар, хуҗасын юксынып, төн буе шыңшып, елап чыккан.* А.Тимергалин. *Хәзер инде күңел өйдәгеләрне генә түгел, урман*

*буйларын, су юлларын, урамнарны, шул урамда йөргән һәр кешесен юксына.* Н.Кәримова

2) *диал.* Югалту, озак күрми торудан борчылу, кайгыру. – *Сиңа адресланган хат, – диде ул, ишарәләп. – Кемдер сине юксынып кулын сузган. Әйе, җылы кулын, ә син аның кулын күрмәмешкә салынасың, янәсе, синең үз хәлең генә хәл.* А.Гыйләҗев

**Юксына башлау** Юксынырга тотыну. *Инде Нияз юксына башлаган иде, тагын шул ук машинада кабат капка төпләренә кайтарып куйдылар.* Ф.Хуҗин

**Юксына төшү** Тагын да ныграк юксыну

**Юксынып бетү** Тәмам, бик нык юксыну. *Әнисен дә, әтисен дә юксынып беткәндер инде...* Г.Гыйльманов

**Юксынып йөрү** Озак вакыт дәвамында юксыну; әле, хәзер юксыну. *Син нигә шулай озак тордың, тагын кара көннәрне юксынып йөрүеңме?* А.Гыйләҗев

**Юксынып кую** Кинәт кенә, бераз вакыт юксыну кичерү. *Яшь чаклар искә төшә дә, кемнедер юксынып куям...* И.Юзеев

**Юксынып тору** Һаман, гел юксыну. *Ә менә шулар өстенә үзеңнең яраткан эшең, инде экраннан китсәң дә, сине юксынып торган тугры тамашачың да булса, менә шулдыр инде ул тулы бәхет.* Шәһри Казан

**Юксынып чыгу** Билгеле бер вакытның башыннан ахырына кадәр юксыну. *Төне буе юксынып чыктым...* Г.Гыйльманов

**ЮКТА** *рәв. сөйл. к.* **югында**. *Йөзеге барда – Сөләйман, йөзеге юкта – сөмәйгән.* Мәкаль. *Айрат абый, сез юкта мендәр өстенә аягын бөкләп менеп утыра да, хан кебек, безне көлдерә.* М.Яһудин. *Татар әйтмешли, печән юкта – салам да печән!* В.Ильясов

**ЮКТАН** *рәв.* 1) Булмаганга, булмау сәбәпле, булмау нәтиҗәсендә. *Канатлар безнең ничә ел Талпынмый торып кыркылды. Дуслыкта ихласлык юктан.* Ф.Гыйззәтуллина

2) Юкка, тиккә генә, нигезсез, тиктомалдан. *Кинәт көзгене исенә төшерүе юктан түгел.* Г.Гыйльманов. *Старостаның, риза булып, улына башка җирдә авыл-йорт корырга ризалык бирүе юктан түгел иде.* З.Мурсиев

**ЮЛ** *и.* **1.** 1) Бер торак пункттан икенче торак пунктка яки аның эчендә йөрү өчен хезмәт итә торган, тапталган яки махсус түшәлгән җир буе, җир кишәрлеге. *Һәр көнне иртән иртүк ул [Сәетгали], мотоциклының сиртмәле биленә атланып, такыр юлдан пырылдап, тирбәлә-тирбәлә, Сыртланга китеп бара.* Ә.Еники. *Язгы көпшәк кар каплаган кыр буйлап чана юлы сузылган.* Р.Батулла

2) Өстеннән яки эченнән хәрәкәт, элемтә алып барыла торган тирәлек. *Киров – элекке Уржум шәһәре була инде... --- ләкин, беренчедән, анда ни су юлы, ни тимер юл бармаган.* А.Тимергалин

3) Үтелгән яки үтелергә тиешле ара. *Без, әнә, картәти белән Мәскәүгә кадәр бардык, ә син шундый якын юлга да икеләнеп торасың.* З.Мурсиев. *Кызларымның сөйләүләренә караганда, болар ул юлны гадәти кырык-илле минут урынына сәгать ярым чыкканнар.* Р.Гаязетдин

4) Берәр тоткарлык, комачау һ.б. аркылы үтәргә мөмкин булган урын. *Сунарчылар һич кенә дә шул ешлыктан кайту юлын таба алмыйлар икән.* Р.Батулла. *Тукталмый ул, югалмый ул, аккан су юлын таба.* А.Нәҗми

5) Берәр җиргә, урынга алып бару өчен сайланган, уйланган уңайлы маршрут, юнәлеш. *Әйдәгез, мин сезне олы урамга кадәр озатыйм, югыйсә үзегез генә юл таба алмассыз.* Г.Әпсәләмов. *Барыр юлын яхшы белгәннәр дә Кайвакытта юлын югалта.* М.Шиһапов

6) Юнәлеш, бару юнәлеше. *Юлчы егет килгән юлына озак кына төбәлеп карап тора да сарымай кыздырылган табага охшаган крояшка күтәрелеп бага...* Г.Гыйльманов

7) Берәр нәрсәдән соң калган эз, сызык. *Озак елаудан аның күз төпләре шешенгән, түгәрәк битендә яшь юллары калган...* Ә.Еники. *Кышкы чанаçаңгы юллары салынгач, дус малайлар белән таудан шуарга, җыелышып, урман ягына китә идек.* Ф.Яхин

8) Язуда хәреф, сүзләр теземе. *Хатының соңгы юлларын Җырлар белән тутыра.* Ф.Кәрим. *Саргаеп, майланып беткән кәгазь битләренә матур гарәп хәрефләре белән тезелгән тигез юллар Мөсәллимнең язмыш тамгасына, яшәү, гомер мәгънәсенә әверелә.* Г.Гыйльманов

9) Җыерчык, сыр. *Еллар үткән, сиздермичә, Маңгайга юллар сузып.* Р.Баһаутдинов

10) Чәчне ике якка аерып тарагач барлыкка килә торган ачыклык. *Яулык читеннән, җем-җем итеп, көмеш алкалары, ике якка аерып үргән чәч юлы күренеп тора.* Г.Бәширов

11) Кая да булса бару һәм шул араны үтү белән бәйле мәшәкатьләр, кыенлыклар; шуңа дип билгеләнгән чыгымнар. *Йөктән юл азыгы тутырган брезент сумкасын алып, башта теге кешегә зур гына бер кисәк ит һәм калай кружка тоттырды...* В.Нуруллин. *Ерак дип, юл мәшәкате зур дип, аның авылдашлары бәйрәмгә кайтмадылар.* М.Мәһдиев

12) Сәфәр, сәяхәт; сәфәр чыгып, йөреп башкарыла торган йомыш, эш. – *Соң, ярар, мәслихәт. Хәерле юл, алайса! – Чәчүгә чыгу буламы ул, уракка төшүме, балаларны укырга бирүме, я булмаса чит авылга кунакка баруммы – һәммәсенә шулай карчыкның рөхсәтен сорап, фатихасын алалар.* Г.Бәширов. *Акъәби аларга [авылдашларына] бик якын кеше, --- шуңа күрә аны ерак юлга, билгесез сәфәргә озату алар өчен шактый зур вакыйга иде.* Ә.Еники

13) Кабатлаулы эшнең бер әйләнеше. *Көлтәгә киткән атлылар, батачума, кичкырын гына кайттылар, --- икенче юлга барып тормадылар: атлар да, йөкчеләр дә хәлдән тайган иде.* А.Гыйләҗев

14) *күч.* Дәвамлы рәвештәге эш, шөгыль, шул юнәлештәге эшчәнлек. *Мөфти Солтановның халык арасында абруе була, чөнки аның дәверендә ахыр чиктә мәчет-мәдрәсәләр күбәя, халык аң-белем, мәгърифәт юлына баса.* А.Тимергалин

15) *күч.* Яшәү рәвеше, эш, шөгыле белән аерымланып торган гомуми яшәеш юнәлеше. *Күңелдә тәртип юк икән – кешенең тормышында да тәртип юк, күңел азгын икән – кеше үзе дә бозык юлда йөри.* Ф.Бәйрәмова. *Изге юлда шәһит булсаң илең өчен, Халкың сине изге итеп дога кылсын.* Г.Мөхәммәтшин

16) *күч.* Тормыш, гомер, яшәү вакыты аралыгы. *Мөхәммәдьярның тормыш юлы турында барлык мәгълүмат шул ике-өч әсәрендәге хәбәрләре белән генә чикләнә.* М.Гайнетдин. *Тукай кыска, әмма иҗат ялкыны белән тулы гомер юлы үтә.* М.Хәсәнов

17) *күч.* Эш итү рәвеше, метод, ысул, алым, әмәл, чара, җай. *Шәмси, аптырабрак калса да, төрле юл берлән ярдәм итүне эзләргә тотынды.* Г.Исхакый. – *Барыбер эзенә төшәчәкләр аның, юлын табачаклар! – диде сөйләүче, ашыкмыйча гына.* Н.Фәттах

18) *күч.* Нинди дә булса эшчәнлектә, эш, хәрәкәт итүдә, эзләнүдә һ.б. алган юнәлеш. *Беренче милли шагыйрь, мәшһүремез Мәҗит әфәнде Гафури хәзрәтләренең «Себер тимер юлы» атлы шигыре минем күземне ачты, мине искелекнең хатасыннан якты юлга күндерде...* Г.Ибраһимов. – *Ләкин мәгънәсезгә корбаннарны арттыру --- шулай ук дөрес юл түгел. – Кайда соң ул дөрес юл?! – дип сорады Задонов.* Г.Әпсәләмов

**2.** *рәв. мәгъ.* Мәртәбә, тапкыр, кат, рәт. *Беренче юлга шушысы [алты чәчәк бәйләме] җитеп торыр. Сәүдәләр уңышлы чыкса, иртәгә тагын килергә мөмкин ич.* Ф.Яруллин

◊ **Юл адаштыру** 1) *к.* **юл адашу**. *Кәҗә тавы битеннән челтерәп аккан чишмә юл адаштырган, диделәр.* Н.Гыйматдинова. *Минем Шарлык авылына юл чыгып киткән төпчек улым Мөсәллимне, юл адаштырмый гына, исәнимин үзебезнең Әмир авылына алып кайтып җиткерсәң иде.* З.Зәйнуллин; 2) Эзәрлекләүчене ялгыштыру, тикшерүне, бутап, ялгыш юлга кертеп җибәрү. *Әгәр юлда барганда артларыннан чит машина тагылса, юл адаштырып, саташтырып бетерә.* Хезмәт даны. **Юл адашу** Юлны, сукмакны, юнәлешне югалту. *Халид бине Вәлид килеп гаскәрне тапмады, юл адашып, бер биек тауга чыкты.* К.Насыйри. **Юл алу** 1) Нинди дә булса юнәлештә китеп бару, юнәлү. *Фазылҗан --- иярләнгән көрән биягә атланып, урманга таба юл алды.* Н.Яһудин; 2) Хәрәкәткә килү, хәрәкәт итә башлау. *Нәсыйхәттән татлы күз яшь юл алды.* Мәҗлиси. *Елга, бер чакрымлап арырак кучеп, яңа юл алган.* И.Хуҗин; 3) Ара үтү, үтәргә өлгерү. *Бераз юл алгач, Хәмит ишүдән туктады да Мәрхәмбикә калган якка күз салды.* М.Хәсәнов; 4) Билгеле бер максат белән яшәү, эшчәнлек күрсәтү. *Үз тарафыннан берәр яңа һөнәргә яисә телгә өйрәнеп, яңа юл алуны мәслихәт тапты.* Г.Исхакый; 5) Нинди дә булса юнәлеш алу, үзгәрү (хәл, вазгыять тур.). *Үзгәрешкә таба юл алган вакыйгаларга сөенәбез.* Ф.Яхин. – *Кемнәр генә юктыр монда, нинди генә бичаралар үз язмышының кай якка юл аласын көтеп ятмыйдыр? – диде Мотаһир.* Р.Кәрами. **Юл арасыннан уку** Язылганның, әйтелгәннең эчке мәгънәсен аңлап алу. *Муса Җәлилнең бик күп шигырьләреннән, --- юл арасыннан укылган фикерләреннән һәм бигрәк тә «Двинага» дип язылган дулкынландыргыч юллардан Латвияне төсмерләп була.* Казан утлары. **Юл асты мәгънәсе** Ачыктан-ачык әйтелмәгән, әмма язмадан аңлашылып торган эчке мәгънә, яшерен эчтәлек. *Биредә [хикәядә] юл асты мәгънәләренә саллы вазифа йөкләнә.* М.Хуҗин. **Юл ачу** 1) Алда торган киртәләрне бетереп, йөрерлек ара хасил итү. *Ул авыл зиратына кадәр карны чистартып юл ачуны да кайгырткан, кабер казуны да оештырган.* Әлки хәбәрләре; 2) *к.* **юл бирү** (*1 мәгъ.*). *Закир кимәдән сикереп төште, җитезлек белән яшь хатынын култыклады да икегә ярылып юл ачкан халык уртасыннан өйгә алып китте.* Г.Ибраһимов; 3) Алга хәрәкәт итәргә, нинди дә булса уңышка ирешергә, үсеш алырга мөмкинлек тудыру. *Башка төрле китаплардан аермалы буларак, әдәби әсәрнең бөеклеге шунда: ул кешеләргә яшәү тәҗрибәсе бирә, аларга үзләрен хис итәргә, тоярга, аңларга өйрәтә, аларның хыялларына һәм өметләренә юл ача.* Ф.Яхин. *Мондый кулай тарафның һәркайсы да Хәмбәл тегермәненә инеш булып коела һәм, теләсә, әгәр бик теләсә, аңа хан тәхетенә юлны ача ала иде.* В.Имамов; 4) Чәчне тараган вакытта, тигез итеп аралап, ике якка аеру. *Чәчен озын итеп үстерә, дәрескә кергәч, чәч юлларын ачып, кыеклап тарап куя.* М.Мәһдиев. **Юл ачылу** 1) Йөрерлек, үтәрлек булу. *Башкомандующий итеп билгеләнгән генерал Щербатов, язгы ташудан соң юллар ачыла башлагач, Казанны ташлап, Оренбургка чыгып китә.* В.Имамов; 2) Мөмкинлек барлыкка килү, форсат туу. *Бәхеткә каршы, миңа бер бүлмә алырга юл ачылды.* Б.Урманче. **Юл аягы** 1) *иск.* Юлдан килгән кешегә бирелә торган бер савыт (аяк) кымыз. *Давыд, юл аягы дип, кәлә-кәлә, самавыр, бик күп чынаяклар, әллә ничаклы пәрәмәчләр алдырды.* Г.Ибраһимов; 2) Юл йөреп берәр йомыш башкарганнан соң бирелгән әҗер яки өстәмә түләү, бүләк. *– Бу сезгә юл аягы, – [дип Николай Иванович] Габделхәй кесәсенә гәзиткә төрелгән әйбер тыкты.* Ә.Галиев; 3) *к.* **юл башы** (*1 мәгъ.*). *Дәүли абзый, менә монысы – юл аягы булыр.* Т.Гыйззәт. **Юл басу** Юлчыларны талау, юлда йөргән кешегә һөҗүм итү. *Авылдан качкан Степашка Косойның каядыр тайгада кеше талап, олы юл басып йөрүен әйтәләр.* Г.Ахунов. **Юл башлап баручы** Беренче булып баручы. *Беренче итеп, юл башлап баручы итеп куйгач, дөям тынды, рәхәтләнеп атлый. Алдан йөрергә, башлап йөрергә күнеккән икән!* Ш.Галиев. **Юл башы** Нинди дә булса эш-хәрәкәт, эшчәнлекнең башлангычы. *«Иттифак әл-мөслимин» партиясе төзелү – XX йөз башы татар милли хәрәкәтенең юл башы дисәк тә дөрес булыр.* С.Максуди. **Юл бирү** 1) Юлдан читкә тайпылып, кемгә дә үтеп китәргә мөмкинлек тудыру; юл сабу. *Машина, сигнал бирә-бирә, урам буйлап рәхәтләнеп тәгәри, тыкрык башын тутырып утырган ишле бәпкәле казлар, каңгылдашып, аңа юл бирделәр, тамак төбе белән эндәшеп, бәпкәләрен читкә чакырдылар.* А.Гыйләҗев; 2) *к.* **юл кую**. *Юләр, җиңдем, дияр, акыллы, юл бирдем, дияр.* Мәкаль. **Юл булсын!** Уңышлы, хәерле сәфәр теләп әйтелә торган сүз. *Гөберле Бака Киеккә: – Хуш килдең, мәрхәбә! – дип, каршысына барып сәлам бирде. – Юл булсын вә аягың мөбарәк булсын!* Ибн әл-Мөкаффаг. **Юл булу** *к.* **юл уңу**. **Юлга аркылы яту** Кемгә дә булса комачаулау, төрле тоткарлыклар ясау. *Берләшү озак бәхеткә, мәңгегә булсын, дип кенә әйтәсе дә бит, юк, сез аяк чалдыгыз, юлга аркылы яттыгыз, иманлы авызымнан чыккан газиз сүзләремә колак салмадыгыз!* Казан утлары. **Юлга киртә кору** Кемнең дә булса эшенә комачау тудыру, омтылышын туктатып калу, алдан чара күрү. *Олуг мәгърифәтчебез, Казанга кайткач, чын-чынлап белем тарату, китаплар язу эшенә керешә, әмма көнчел холыклы адәмнәр аның юлына гел киртәләр корып куя.* Р.Рахман. **Юлга салу** 1) Нинди дә булса эшне, эшчәнлекне көйләп җибәрү, җайга салу, җайлау, рәтләү. *«Хөсәения» мәдрәсәсе шәкерте Заһид Шәркый-Йосыповка 1924 елның башында казакъ телендә «Юл» газетасын редакцияләү, газета чыгаруны юлга салу эше йөкләтелә.* Л.Хәмидуллин; 2) Дөрес юлдан тайпылган кешене намуслы тормыш алып барырга өйрәтү. *Кешене изге юлга салу, аны юлдан яздыруга караганда, мең тапкыр кыенрактыр.* М.Хәбибуллин. **Юлга төшү** 1) Кирәкле җиргә илтә торган юлны табу, шул юл буйлап бара башлау. *Алар, аның кебек ятимә хатыннар, клубтан чыгып, авылларына кайтыр юлга төшкәч, --- үзләренә бирелгән бүләкләрне --- тау үрендә яткан Бүләк урманына җиткәч кенә ачып карарга булдылар.* А.Хәлим; 2) Тиешле юнә-

лештә, чынбарлык таләп иткәнчә, дөрес, гадел эш итү. *Тугры юлга төшсәңез, үз халкыңызга әллә ничаклы хезмәт итәрсез...* Г.Ибраһимов. **Юлга чалыш килү** Юл уңмау, теләккә ирешүдә комачаулар барлыкка килү. **Юлда аунап ятмый** Кадерсез, кирәксез түгел. *Юньле эш юлда аунап ятмый шул ул.* Шәһри Казан. **Юлдан аздыру** *к.* **юлдан яздыру**. *[Пәйгамбәребез] «Йөрәгегезне шушы дөнья малы гына хак юлдан аздырачак», – дип әйтә.* Риваять. **Юлдан азу** Тиешле тәртиптән, инсафтан чыгу, җәмгыятьтә кабул ителгән нормаларны бозу; саташу, ялгышу. *Изге, игелекле юлдан азган залимнәргә үзләренең түбән инстинктларын тормышка ашыру өчен юллар ачылды.* И.Вәлиулла. **Юлдан чыгу** *к.* **юлдан азу**. *Алар мине дә ысулы җәдидәгә үгетләп караганнар иде дә, әмма тугры юлдан чыгар исәбем юклыгын күргәч, кире чигенделәр.* М.Галәү. **Юлдан шашу** *к.* **юлдан азу**. *Адәмнәр гүя юлларыннан шаштылар.* Г.Ибраһимов. **Юлдан яздыру** Азгынга, әхлаксызга әйләндерү, тәүфикъсызландыру. *Нәфес – шайтан, ул адәмнәрне юлдан яздыра.* Ш.Бабич. **Юл калдыру** Мөмкинлек бирү, каршылык күрсәтмәү. *Кырыс холыклы бабайның: «Кеше булганчы укыйсың!» – дигән сүзләре чигенергә юл калдырмый иде.* Р.Вәлиев. **Юл кәгазе** *к.* **юллама** (*1 мәгъ.*). *Фәсхинең кулына «Өч нарат» совхозының башкаручысы итеп билгеләнгән юл кәгазе тоттырдылар.* Ф.Сәйфи-Казанлы. **Юл кешесе** Юлчы, сәфәрдәге кеше, мөсафир. *Килгән кешедән, син кем, нинди йомышың бар, дип сорамыйлар, башта ашарга утырталар, юл кешесе юлда арыгандыр, тәүдә бераз хәл җыйсын, диләр.* З.Мурсиев. **Юл килү** 1) Сәфәрдә булып, юлда йөреп килеп керү. *– Юл килеп туңгансыздыр, мин самавырны яңарттырыйм әле, сезнең ямщикны да туйдырсыннар... – дип сөйләнә-сөйләнә, Рөстәм бәк әфәнде ишектән чыгып китте.* Г.Рәхим; 2) Юл билгеле җирдән икенче җиргә алып бару. *Ә тимер юл станциясеннән колхоз үзәгенә, асфальт ук булмаса да, чуер таш түшәп салынган олы юл килә.* В.Нуруллин; 3) Юл уңае булу. *Моннан соң карчык кызның агасы каршысына туктый да аңар сеңелесе исеменнән хитаб итеп җырлый: – Борылышка борылыш юл килсә, борылырсыңмы, агакай?* Г.Рәхим. **Юл киселү** Чарасыз хәлдә калу, мөмкинлек бетү. *Су буена төшкән саен бозларга карыйм: бозлар кузгалдымы – синең кайтыр юлың киселә.* Ф.Яруллин. **Юл кисү** 1) Кемнең дә булса барган юлында комачау ясау, аркылы тору. *Кызу гына чабып килгән ат, кинәт туктаган уңайга борылып китеп кызның каршысына чыкты да, үзенең биек озын гәүдәсе белән аның юлын кисте.* Н.Яһүдин; 2) *к.* **юл басу**. *Анда [учак тирәсендә] утыручылар да кеше аягы басмаган караңгы урманда каяндыр юл кисеп, мал басып кайткан юлбасарларны хәтерләтәләр иде.* Г.Бәширов. **Юл кисүче** Юлбасар, юл басучы, талаучы. *Кем син үзең? Юл кисүче? Иблис мәллә?* Һ.Такташ. **Юл котлык (котлыгы, коты)** 1) *бор.* Юлга чыкканда үзең белән алган кот, бөти; 2) Яхшы теләк мәгънәсендә әйтелә. *Сиңа – юл котлык (коты, котлыгы), миңа – өй котлык (коты, котлыгы).* Әйтем. **Юл кую** 1) Үзең теләмәгән эшкә яки нинди дә булса хәрәкәткә, чараларга түзеп тору, шуңа каршы көрәшмәү. *Әллә син мине һәрбер башбаштаклыгыңа юл куяр дип уйладыңмы?* А.Вергазов; 2) Ташлама ясау, каршы килмәү, рөхсәт итү. *Икесе дә эрудитлар, белмәгән нәрсәләре юк, әмма мактаныша башласалар, берсе икенчесенә юл куяр димә.* А.Хәсәнов. **Юлны буу** Нинди дә булса омтылышны, берәр төрле хәрәкәтне туктатып калу. *Усал ерткыч теш ырҗайта, куркыныч авазлар... Агулы еланнар юлны буа...* Р.Камал. **Юл өзелү** Юл үтә алмаслык, йөри алмаслык хәлгә килү. *Кыш җиткәч кенә [дөяләрне] хуҗалары тотып ала, чөнки кышын даланы кар баса, машина юлы өзелә.* М.Маликова. **Юл өстендә** 1) Хәрәкәткә комачаулап, юл уртасында. *Бер кочак печән күтәреп, «әллү гендәем, бәллү гендәем» дип көйләп килгән Газинур юл өстендә басып торган Сәлимгә: – Әзрәк читләш әле, егет, күлмәгеңә печән ябышмагае, – диде.* Г.Әпсәләмов; 2) Узышлый юлга якын, юл уңаенда. *Чаллыдан Казанга барышлый, юл өстендә, Таулар Иле дигән авыл бар.* А.Хәсәнов. **Юл сабу** Читкә тайпылып юл бирү. *Көчле юл саба икән, көчсезнең куанычтан башы әйләнә, ди.* М.Галиев. **Юл сызу** План төзү, алдан уйлап эш итү. *Безгә юл күрсәтеп, юл сызып, дөрест вә тугры юлга димләп, шуңа өндәүче булмаса, без бер кыйблага таба бара алмас идек, яңлышыр идек, таралыр идек...* Г.Исхакый. **Юл тоту** 1) Юнәлү, кая да булса бара башлау. *Ул [Суфи Аллаһияр] хаҗ кылырга ниятләп, Казан ягына таба юл тота.* А.Гайнетдинов; 2) Билгеле бер чиккә таба, билгеле якка үзгәрү, йөз тоту. *Каршылыклар активлашу шартларында кара кытайлар тәхете тотрыксызлыгы тирәнәю, таркалу ягына юл тота.* М.Гайнетдин; 3) Билгеле сәясәт алып бару, берәр максатка омтылу, эш йөртү. *Сүз сөрешеннән Ихласның якты киләчәккә юл тотканын аңлады.* А.Гыйләҗев. **Юл төшү** 1) Юл өзелеп торганнан соң яңадан йөрерлек хәлгә килү. *[Әнкәсе] Гөлбану кызым белән Закир кияүне чана юлы төшүгә кунакка алдырам, дип әйтте, ди.* Г.Ибраһимов; 2) Берәр җиргә барырга туры килү, насыйп булу, кирәк чыгу; 3) Юл уңае туры килү. *Хуҗалар безне: «Юл төшсә, туп-туры үзебезгә керегез», – дип озатып калды...* А.Гыйләҗев. **Юл уңае** Китеп бара торган юнәлеш белән туры килгән, шул юнәлешнең өстендә булган. *– Суташ сезгә юл уңае түгел бит, – диде Фидая.* М.Маликова. **Юл уңаен(д)а** Кая да булса барышлый, китеп барган уңайдан, юлагай. *Эш төшеп Назарбәккә баруым әле, юл уңаеннан сезгә сугылып чыгарга булдым.* Р.Мирхәйдәров. **Юл уңайлый** 1) *к.* **юл уңаен(д)а**. *Хәлегезне ишеттем дә Юл уңайлый бер кердем.* К.Булатова; 2) Юлда барганда. *Әйдә, илтеп ташлыйм, Юл уңайлый гәпләшербез дә.* Р.Вәлиев. **Юл уң булу** *к.* **юл уңу**. *Юлы уң булсын да моның кебек изге җаннар адым саен очрап торсын иде әле!* В.Имамов. **Юл уңу** Йөрүнең, сәфәрнең, йомыш-юлның нәтиҗәсе әйбәт булу, уңышлы тәмамлану. *Җиләкчеләрнең юлы уңган: икесенә чүмәкәй тулы ике савыт җиләк алып кайтканнар.* С.Поварисов. **Юл чыгу** 1) Кая да булса барырга дип юл алу, сәфәргә китү. *Ялан өстенә эңгер-меңгер иңгәч, ерактагы авыллардан килгән кунаклар юл чыгарга җыена башлады.* В.Имамов; 2) *к.* **юл төшү** (*1 мәгъ.*). **Юлын бүлдерү** *к.* **юлын бүлү**. *Ышыграк катларда кар бөртекләре бер урында бөтерелә, җил улый, әйтерсең юлын бүлдергәнгә ачулана, урамның ике ягына өелгән кар көртләрен пыран-заран китерергә җыена кебек.* Г.Әпсәләмов. **Юлын бүлү** Хәрәкәт итүне туктатып калу, тукталырга мәҗбүр итү. *Ике арага ташласаң, көзге шунда ук үтеп булмаслык дәрья-суга әверелә дә явыз затларның юлын бүлә.* Г.Гыйльманов. **Юлында тору** Кемнең дә булса

омтылышына комачаулык тудыру, теләкләренә каршы булу. *Кызның елап китүе [йоласы] аның язмышы юлында торган серле көчләрне җиңү, явыз рухларны йомшарту өчен кирәк, дип саналган.* Йола һәм уен җырлары. **Юлын таптап табан төшү** Берәр эш, әйбер артыннан күп йөрергә туры килү. **Юлыңа ак җәймә** 1) Юлга чыккан кешегә яхшы теләк буларак әйтелә. – *Синдә тырышлык, үҗәтлек җитәрлек – юлыңа ак җәймә, – ди аңарга Мирсәет, кулын биреп.* Р.Мөхәммәдиев; 2) *к.* **юлыңны кара**. *Энекәш, андый уй белән килсәң, дүрт ягың кыйбла, юлыңа ак җәймә.* Ф.Сафин. **Юлыңны кара** «Китә бир, үтеп кит, юлыңда бул» мәгънәсендә. *Лучше син, егет, тыгылып йөрмә, кайткансың икән, кунак бул да әнә юлыңны кара!* Ә.Еники. **Юлың такыр** *к.* **юлыңны кара**. *Әйдә выжт – сыптыр, юлың такыр чакта.* Р.Хәмид. **Юл яздыру** *к.* **юл адаштыру**. *Ә мин ул арада, юл яздырып, әллә кайларга китеп бардым.* Г.Бәширов. **Юл язу** *к.* **юл адашу**. *Юл яздым китеп еракка, Хыяллар бармак яный. Буй җитмәс җиргә үрелдем – Мин әле һаман сабый.* Р.Гаташ. **Юл ялгышу** *к.* **юл адашу**. *Юл ялгышып, адашып килеп чыккан адәмнәр генә, су буенда бала җитәкләп йөргән «су җене» белән «су анасын» күреп, тизрәк авылга кайтып китү ягын карыйлар иде.* Г.Гыйльманов. **Юл яру** *к.* **юл ачу**. *Ул да шулай, күкрәген калкан итеп, дөреслеккә юл ярып бармакчы иде.* М.Маликова

**ЮЛАГАЙ** *рәв. диал.* Юлда; юл уңаенда, китеп барган уңайда. *Юлагай очрату*

**ЮЛАЙ** *и. диал.* 1) Юл чыгымнары

2) Юлда табылган байлык; юламанга бирелә торган акча, әҗер

**ЮЛАКАЙ** *рәв. диал. к.* **юлагай**. *Юлакай кереп чыгарга кирәк урын*

**ЮЛАМАН** *и. иск.* Юлаучыларга, сәүдәгәрләргә юл күрсәтү һәм олау, кәрваннарны озата бару белән кәсеп итүче кеше; юл күрсәтүче, кулавыз. *Ямannан яман кем яман? Ят явына юламан.* Мәкаль. *Тулган ай юламан булып алдан барды, кара атка җайдак менгән кара япанчалы кызга иң туры сукмакларны табышты.* Л.Зөлкарнәй

**ЮЛАТУ** *ф. диал.* 1) Юллау, җибәрү. *Хат юлату*

2) Үз янына җибәрү, якын китерү. *Яратмады ярамсакны, Юлатмады ялагайны. Ярамсактан, ялагайдан Артык күрде Алабайны.* И.Киньябулатов. *Якын юлатмасын түбән затларны.* Безнең мирас

**ЮЛА́У** *ф. диал.* Юлны, маршрутны, юнәлешне берәр нәрсәгә юнәлтү. *[Сыер] Үзе генә булса, игенгә якын юламый ул.* М.Фәйзи

**ЮЛАУЧЫ** *и.* **1.** Сәфәрдә йөрүче, сәяхәтче, юлда йөрүче. *Сабанчы яңгыр тели, юлаучы – коргак.* Мәкаль. *Урамда ат пошкырганы ишетелде, арба кигиләрен чыгырдатып, ниндидер бер юлаучы узды.* Г.Бәширов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Юлда йөргән, юлда булган. *Саҗидә, почта юлаучы атларының кыңгыравы кадәр зур чулпысын чылтыратып, исле сабын белән кул юарга чыгып китте.* Г.Исхакый

2) Юл уңаена туры килгән, бер юнәлештә булган. *Көймә бүген яки иртәгә китәчәк, тик җайлы, юлаучы җил генә көтеп ята иде.* К.Насыйри

3) *күч.* Билгеле бер очракта, чорда гына иптәш булган, нигездә иш булмаган (сәяси төркемнәр, сыйныфлар тур.). *Юлаучы көчләр*

**ЮЛАУЧЫЛЫК** *и.* 1) Юлаучы булу, юлда йөрү эше

2) Пассажир булу. *Вокзалның эчетышы вак-төяк киосклар белән тулган, --- һәр юлаучылык фирмасының үз мәркәзе эшли, аларның вәкилләре, вокзал мәйданында бер-берсен уздыра-уздыра, мөсафирларны үз автобусларында барырга өнди.* Т.Әйди. *Бигрәк тә безнең Русия кебек мөсафирларга хезмәт күрсәтүче инфраструктуралар зәгыйфь, яралгы хәлендә генә булган илдә юлаучылыкның бу ягы аеруча зур әһәмияткә ия.* Татарстан яшьләре

3) *күч.* Нигездә иш булмыйча, билгеле бер очракта, аерым бер чорда гына булган иптәшлек (сәяси төркемнәр, сыйныфлар тур.). *Такташның Октябрь елларында революциягә юлаучылыктан пролетариат әдәбиятына союздашлыкка таба үсеше аның символистидеалистлыктан --- социализм төзелеше --- күренешләрен шигъри сурәтләрдә күрсәтү һәм тәгъбир итүгә килеп ялгану рәвешендә барды.* Фәнни Татарстан

**ЮЛАЯКЛЫК** *и.* 1) Юлда йөргәндә берәр йомыш башкарган өчен бирелгән әҗер, бүләк

2) Юлга чыккан кешегә бирелә торган бүләк. *[Шәйбәк – көтүчеләргә] Хәерле юл, балалар, Алла сезгә исәнлек бирсен (кулындагы әйберләрен Тимеркәйгә бирә). Менә бу сезгә карчыгымнан юлаяклык.* Г.Ибраһимов

**ЮЛӘР** *с.* **1.** 1) Акылсыз, тиле, дивана. *Мәгълүм ки, әкиятләрдә, гадәттә, күрер күзгә йолкыш кына булган берәр диванарак кеше --- билгеле бер ноктага кадәр мәгълүм шартларда юләр кеше маскасын – битлеген киеп йөри дә, вакыты җиткәч, аны салып ташлап, үзенең асыл сыйфатын – зирәклеген күрсәтә.* Ф.Хатипов

2) Уйламыйча юләрләрчә әйтелгән, акыл белән нигезләмичә ниятләнгән яки эшләнгән. *Сабый башына шундый юләр уй килеп торуын күр әле.* В.Нуриев. *Авыл дип беләсеңме әллә син анда, әллә нинди усал бәндәләргә очрарсың, чыгарып ташла андый юләр уйларыңны...* К.Кара

3) Акылга сыешмаган, кызык өчен генә әйтелгән, эшләнгән. *Көрәгенә таянган хәлдә кайчандыр колагына чалынган бер юләр мәзәкне исенә төшереп, авыз чите белән генә елмайгандай итте.* А.Хәлим. – *Ташла бу юләр гадәтеңне, юкса тунап, тиреңне салдырам бит, – дип, берәр тапкыр тал чыбыгы белән [бүре баласы] Чатанга сырты буйлап сыптыруының да файдасы тимәде.* А.Хәсәнов

4) Мавыгучан; тиле, җилбәзәк. *Телең ни сөйләгәнне колагың ишетсен, юләр кыз!* А.Гыйләҗев. *Дарулары аның бер йолдызда Ялкынланган юләр йөрәкнең.* В.Галиев

**2.** *и. мәгъ.* 1) Акылга зәгыйфь, исәр, дивана кеше. *Акылны юләрдән өйрән.* Мәкаль. *Юләрләр мәҗлесендә акыллы кеше мәзәк күренер.* Мәкаль. *Үзең юләр булсаң да, сүзләрең шактый акыллы күренә.* Р.Вәлиев

2) Җиңелчә уйлый торган, ахырга кадәр уйлап бетерми торган кеше, сантый. *Аяз көнне яңгыр көткәнмен икән мин юләр.* А.Алиш. – *Юләр мин, чын-чынлап юләр, – дип сукте ул үзен.* А.Вергазов

**3.** *рәв. мәгъ. к.* **юләрләрчә**. *Әмма бу көлүе каһкаһәле юләр көлү түгел.* Ф.Яхин

◊ **Юләр (кеше) әйтмешли** «Уңайсызрак булса да, җае чыкканда сорыйм әле» мәгънәсендә. *Юләр кеше әйтмешли, әллә үз толымың түгелме?* Н.Кәримова. **Юләр сату** Юләрләрчә сөйләшү, кылану. *Нишләп тузгыган корт иле кебек гөҗли, шаулый, юләр сата бу яшь-җилкенчәк һәм инде күптән акыл утыртырга, сабырланырга тиешле чем кара мыеклы ир-ат халкы?* Т.Әйди

**ЮЛӘРБАШ** *и. сөйл.* Беркатлы, ахырын уйлап бетерми торган кеше. *Ә ул, юләр баш, артыннан күзәтү барлыгын да искәрмичә, өеннән сумка күтәреп чыгып йөгерә.* Н.Акмал

**ЮЛӘРЛӘНҮ** *ф.* 1) Юләргә әйләнү, исәрләнү, акылдан язу. *Шушы хәлдән соң [Сена елгасында чалкан яткан эт – Кокотканың үләксәсен таныгач] Франсуа юләрләнә...* М.Хуҗин. *Тилебәрән орлыгы ашап, өч малай юләрләнде.* Р.Батулла

2) Ялгыш гамәл кылу, ахырын уйламыйча эшләү. *Бу чәчәкләрне күргәч, тагын Рабиганың, юләрләнеп, мине калдырып китүе исемә килеп төште.* Г.Рәхим. *– Юләрләнеп, укуыңны ташлый күрмә, Гафиятулла, – диде [Сөембикә].* Р.Газиз

3) Үзен җитди тотмау, җитдилеген югалту; табигый булмаганча кылану, шаяру, маймыллану. *Ирина, коеп яуган яңгыр астында калып, такмаклый-такмаклый, бии-бии, башта берүзе генә юләрләнде.* Казан утлары

**Юләрләнә башлау** Юләрләнү билгеләре күренү. *Кайтып керә дә, бишектәге нарасыйны кулына алып, юләрләнә башлый: иреннәрен бөрештереп сызгырган була, бүлмә буенча әйләнеп бөтерелеп йөри.* Э.Касыймов

**Юләрләнә язу** Чак кына юләрләнми калу. *Ханым, авыр кайгыдан юләрләнә язып, ашкынып больницага килеп керә.* З.Мурсиев

**Юләрләнеп алу** Бераз, берара, кыска вакыт арасында юләрлек күрсәтү. *Адәм баласына бер юләрләнеп алу ярый анысы.* Р.Бәшәр

**Юләрләнеп бару** Акрынлап, азазлап юләрләнү. *Кеше диган олуг затларның кайберләре әллә бөтенләй юләрләнеп баралармы дип уйлыйм мин еш кына.* А.Хәсәнов

**Юләрләнеп бетү** Тәмам, бөтенләй юләрләнү. *Хатыны Гөлҗиһан, иренең юләрләнеп бетүенә ышанып бетмәсә дә, аның белән тормау, бүтән иргә чыгу турында уйлый, приказчик Мөхәммәтҗан да «абыстай әле артык карт түгел, акчасы булса, аның белән торырга мөмкин», – дип уйлый.* Г.Җәлилова

**Юләрләнеп йөрү** Әле, хәзерге вакытта юләрләнү. *Шулай да кире борыласы итмәде – берәрсе күреп торса, нигә юләрләнеп йөри икән авыл советы рәисе, дип бәяләве мөмкин ич.* М.Хуҗин

**Юләрләнеп китү** Кинәт, нинди дә булса берәр сәбәп белән юләрләнү. *Йәгел шул әҗәт турында уйланып йөреп юләрләнеп китәрсең.* Ф.Яруллин

**Юләрләнеп кую** Кинәт, көтмәгәндә юләрләнү. *Музыкасы да башта әллә кайчангы хәлләрне яңартып шашындырды да, юләрләнеп куймагае бу тагын дип, шып туктап калды.* Казан утлары

**ЮЛӘРЛӘ́РЧӘ** *рәв.* Юләрләр сыман, юләрләргә охшаш рәвештә. *Мин ун яшемнән кызларга гашыйк була башладым. Ошаганнары артыннан юләрләрчә тагылып йөрдем, акылымнан шашар дәрәҗәгә җиттем.* Ф.Садриев

**ЮЛӘРЛЕК** *и.* 1) Юләр булу сыйфаты, хәле. *Менә инде көне буе шуны саклап утыр, әгәр гомер буена шул юләрлегендә булса, аның белән ничек торырсың?* Г.Камал

2) Юләрләрчә, уйламыйча эшләнгән эш, кыланмыш, әйтелгән сүз. *Кем белә, бәлки, ул әле дә теге чактагы юләрлеге өчен үкенеп, Хәмидә апаны сагынып-саргаеп яши торгандыр.* В.Нуруллин

**ЮЛӘРСЕТҮ** *ф.* 1) Юләргә санау, юләр дип уйлау. *Ләкин ул мине бераз юләрсетә, һаман да бер-бер җиремнән көлке табып мыскыллый, «вакытсыз» картайган, ди, бабай, ди.* Ш.Камал. *Чынлап та, аның шигырь язучы кешеләргә юләрсетеп каравы йөзенә чыккан иде.* Ф.Җамалетдинова

2) Юләр сыман итү, юләргә әверелдерү. *Ышанмасаң – сына утта, суда, – Юләрсетмә биреп тик шөһрәт.* Н.Гамбәр

**Юләрсетеп җибәрү** Кинәт юләрсетү. *Бәхет тә кайчак кешене юләрсетеп җибәрә икән.* Г.Әпсәләмов

**ЮЛӘ́Ү** *ф. диал.* 1) Тегү, җөйләү. *Кечкенә чакта [әни] барыбызга да бишмәтенә, түбәтәенә, бүрегенә, бияләенә чаклы үзе юләп кигезә иде.* Г.Толымбай

2) Дәвамын ялгау, өстәп тегү. *Өстемдәге кижеле күлмәгем – Кештәгенә комач юләдем.* Җыр

**ЮЛБАРЫС** *и.* 1) Мәчечәләр семьялыгыннан йомры башлы, җирән төстәге өслектә аркылы кара буй-буй юллары булган тиреле, бик көчле эре ерткыч хайван. *Эт, бергә булса, юлбарыска өрә.* Мәкаль. *Иреккә чыккан юлбарыс, арысланнарны кабат читлек эченә кертеп булмый.* В.Имамов

2) *күч.* Бик көчле, кызу яки усал, явыз кеше. *Йөзенә ерткыч юлбарыс төсе чыккан, күзен кан баскан, җиңенә фин пычагын тыккан да, син – провокатор, дип өстемә ташланды ич!* Г.Ибраһимов

◊ **Юлбарыс кебек (төсле, шикелле, рәвешендә)** 1) Юлбарыстай көчле, елгыр һәм ярсу (кеше тур.). *[Барс, Юлбарыс исемнәре] Ир бала юлбарыс кебек көчле булып үссен диган теләктән чыгып кушылган.* Р.Безертинов; 2) Көчле, кыю рәвештә. *– Яле, я, я! – диде ул, Фәләхкә таба баласын яклап һөҗүмгә күчкән ана юлбарыс шикелле ыргылып.* В.Нуруллин

**ЮЛБАСАР** *и.* 1) Юлаучыларга һәм юлчыларга һөҗүм итеп, малларын, байлыкларын талау белән шөгыльләнүче җинаятьче. *Риваятьтә патша Михаил Фёдорович заманында монда үтә явыз хатын Дунька юлбасар качып яткан дип сөйләнә.* А.Тимергалин. *Вак-төяк малга кызыккан угрының кулын кисәләр, сәүдәгәрне талаган юлбасар шундук башсыз кала.* В.Имамов

2) Гомумән урлау-талау белән шөгыльләнүче кеше, кораллы карак. *Син минем үткер хәнҗәр тотып, юлбасар булып тар тыкрыкка чыгуымны көтәсеңме әллә?* А.Гыйләҗев. *Ә тегеләр очраклы хулиганнар гына түгел, урлашу-талау белән күптән шөгыльләнүче тәҗрибәле юлбасарлар булырга кирәк: шәп сугышалар, аяктан егарга тырышалар Нуруллаяны.* В.Нуруллин

3) *күч.* Илбасар, баскынчы. *Юлбасарлар таптый җиребезне, Ватан сугышына мин китәм.* Ф.Кәрим

4) *күч.* Хыянәтчел кеше, хаин. *Ояты юк, сатлык юлбасарның Бүген менә йөзе ачылды.* Һ.Такташ

5) *күч.* Мал-туарга зыян салучы ерткыч хайван. *[Коллилар нәселеннән булган этләр] Кирәксә, бүре диган юлбасар белән бугазга-бугаз килергә дә куркып тормыйлар алар.* А.Хәсәнов

**ЮЛБАСАРЛЫК** *и.* Юлбасар булу, юлбасарга чыгу. *Кенәз белән килешмичә качкандыр, хәзер әнә Всеволод җыйган дәүләтнең дәрәҗәсен төшереп, күрше халыкларга ышанычын югалттырып, юлбасарлык кылып йөри.* М.Хәбибуллин. *[Бүре баласы] Чатан шулай Пошилар усаклыгы урман массивында юлбасарлык иткән эт-маэмайлар бандасының башлыклары булып куйды.* А.Хәсәнов

**ЮЛБАШЧЫ** *и.* 1) Юл күрсәтүче кеше. *Ригстанны тамаша итәргә киттем. Миңа бер юлбашчы бирделәр.* З.Бигиев

2) Эш башында торган кеше, әйдәп баручы, юнәлеш бирүче кеше; җитәкче, башлык. *Алар 622 елда хаҗга килгәч, Мөхәммәд пәйгамбәргә бәйгать*

*китереп, аны үзләренең юлбашчылары һәм остазлары итеп танышйлар.* А.Тимергалин. *Ул [Канзафар] санаулы көннәр эчендә үз кул астына яңа отряд туплый һәм июль башында Ногай юлындагы фетнәчеләрнең юлбашчысына әверелә.* В.Имамов

**ЮЛБАШЧЫЛЫК** *и.* 1) Юл күрсәтеп бару эше, юлбашчы (*1 мәгъ.*) шөгыле. *Кәрван юлында юлбашчылык белән шөгыльләнү*

2) Юлбашчы вазифасы, оештыру, юнәлеш бирү эшчәнлеге. --- *журналистлык һәм революционерлык белән консервативлыкның синтезы, юлбашчылык сәләте – миңа да хас сыйфатлардыр.* Г.Акыш. *Киеренке шартларда дини юлбашчылык вазифасын башкару Гыйззәтулла хәзрәткә, әлбәттә, авыр булган.* Казан утлары

**ЮЛБАШЧЫЛЫ́К ИТҮ** *ф.* 1) Юл күрсәтү, алдан ияртеп бару. *Ригстанда миңа юлбашчылык иткән кешедән бер мәгълүмат та ала алмыйча, Ригстаннан чыктым.* З.Бигиев

2) Җитәкләү, оештыру, юнәлеш бирү, башлап йөрү, эш башында тору. *Бу хәерле эшне кулына алганы өчен вә балаларга дини тәрбия кертүдә юлбашчылык иткәне өчен, «Хатын-кыз җәмгыяте хәйриясе»нә рәхмәтләр укымый хәлемез юктыр.* Г.Исхакый. *Төшеңдә сарык көтүчесе булсаң, бәклек һәм юлбашчылык итәрсең, ди Мөхетдин бине Гарәби.* Ф.Яхин

**ЮЛБАШЧЫЛЫ́К КЫЛУ** *ф. к.* **юлбашчылык итү**. *«Көтү башы» дип атап йөртә торган берничә сыер бар. Кайтуга чыгудамы, туклауга төшүдәме, бер якка борылыргамы, – эти шул сыерларга, исемнәре белән кычкырып, кая барырга икәнен әйтә; тегеләр дә, алга чыгып, юлбашчылык кылалар.* Г.Ибраһимов

**ЮЛГА** *бәйл. сүз к.* **юлы**. *– Бар, Хәйретдинов, – диде аңа Миңнулла, – бу юлга азат итәм мин сине.* В.Нуруллин

**ЮЛДАШ** *и.* 1) Бер-берсенә карата: юлга бергә чыккан, сәфәрдә бергә йөргән кешеләр. Юргалы белән юлдаш булма. Мәкаль. *Әйткәнемчә, миңа зиратка барырга юлдаш кирәк.* Б.Рәхимова. *Мондый юлдаш белән ерак юлга ныклы әзерлек белән чыксаң да таманча гына әле.* А.Хәсәнов

2) Иптәш, дус, шәрик. *Ирне юлдашына карап танышйлар.* Мәкаль. *Юлдашлары да шундый ук көчле шәхесләр булды. Аларның сөйләшүләрен тыңлау үзе бер гыйлем дөньясына сәяхәт иде.* А.Әйделдинов

3) Әйдәп барырлык кеше; көрәштәш, мәсләктәш, теләктәш. *Тик бу эшкә безгә бер чын-чын гаярь юлдаш кирәк, Кем ярый? Күрсәтегез, башлык итәрдәй баш кирәк!* Б.Мирзанов

4) *күч. сир.* Никахлы ир яки хатын. *Яраткан кешесенә файда китерергә әзер тору, фидакярлек, тугрылыклы юлдаш булу, хезмәте белән сөйгәненең яшәешен бизәргә омтылу бу хатынга карата хөрмәт уята.* А.Әхмәдуллин

5) *күч.* Юлга чыккан, нинди дә булса эш башлаган кешегә ярдәм итәрлек сыйфат, гамәл, күренеш яки фатиха, теләк. *Хәерле сәгатьтә, үзеңә изге гамәлләр юлдаш булсын, олан...* В.Имамов. *Сәламәтлек юлдаш булсын сиңа, Бәхеткәең булсын гомерлек.* В.Хәйдәрова

**2.** *с. мәгъ.* Юлда, сәфәрдә бергә булган. *Юлдаш агайларым уңышлы сәүдә иттеләр.* А.Тимергалин. *Якыннан белгән, аралашкан, ризык бүлешкән, балыкка барган, сунарга йөргән юлдаш иптәшләре, сердәш көрәштәшләре, мөгаен, аның бу мактаулы сыйфатларына тагын ни дә булса өсти алырлар иде.* А.Гыйләҗев

**ЮЛДА́Ш ИТҮ** *ф.* 1) Берәүне юлдаш буларак үзе белән алу, кем белән булса да бергә юлга, сәфәргә чыгарга алыну. *Дусларыннан Харҗә бин Синан дигән кемсәнәне үзенә юлдаш итеп, Әвәс шәһәре тарафына киттеләр.* К.Насыйри. *Бөре суы буендагы карьяләрнең береннән бер итекче мөселманны үзенә юлдаш итеп, Хиҗаз сәфәренә рәван улды.* Г.Камал

2) Берәү белән никахка керү, хатынлыкка яки ирлеккә алу. *Җир җимертеп эшләгән кешене кем генә тормышта үзенә юлдаш итмәс икән?!* Р.Кәрами

3) *күч.* Юлга чыккан, нинди дә булса эш башлаган кешегә, гомумән тормышта уңыш теләп фатиха бирү, яхшы теләк теләү. *Ходай Тәгалә аңа киләчәктә исәнлек бирсен, илһам дулкыннарын юлдаш итсен!* Х.Миңнегулов. *Ходай Тәгалә Сезгә иминлек, сәламәтлек, уңышлар юлдаш итсен.* Г.Шәйхи

4) *күч.* Нинди дә булса сыйфат, фигыль, гамәл, күренеш белән ярашу, үзеңдә булдыру. *Аның җырлары рухыбызны сафландыра, җаныбызны дәвалый, ул җырларны ничә буын үзенә юлдаш итте...* Г.Зәйнашева. *Табигатьне, чисталыкны яраткан, намуслылыкны үзенә юлдаш иткән Барый башкалардан да шуны таләп итә.* Л.Минһаҗева

**ЮЛДА́Ш КЫЛУ** *ф. к.* **юлдаш итү**. *Сансыз гаскәр кәрванга юлдаш кылды.* Фирдәүси. *Рәхмәтең киң, шул кяфер дөньясында җаным чыкканда, шул гөнаһлы тәнемнән мөселман җаным аерылганда, йа Рабби, иманымны юлдаш кыл!* Г.Исхакый

**ЮЛДАШЛЫК** *и.* 1) Юлдаш булу сыйфаты. *Ат – юлда, кеше юлдашлыкта сынала.* Мәкаль. *Нәфрәтләнгән кеше белән юлдашлык, әлбәттә, мөшкелдер.* Г.Ибраһимов

2) *күч.* Янәшә, параллель рәвештә бару яки дәвам итү, ярашу күренеше. *Бу ике башлангычның юлдашлыгы метод һәм стильләр структурасында һәрвакыт күренеп торды.* Казан утлары

**ЮЛДАШЛЫ́К ИТҮ** *ф.* Юлдаш булу. *Әкияттә өстенлек иткән эстетик вазифага төрле дәрәҗәдә идея вазифасы да юлдашлык итә.* Л.Җамалетдинов. *Адәм баласына һәрдаим ныклыгы юлдашлык итсә, картаймыйча гына яшәр иде.* Ф.Яхин

**ЮЛДАШЛЫ́К КЫЛУ** *ф. к.* **юлдашлык итү**. *Теләгемә мәкер юлдашлык кылды.* Ф.Яхин

**ЮЛЛАМА** *и.* 1) Берәр кешене кая да булса билгеләүне яки юнәлтүне белдергән рәсми документ; *русчасы:* **путёвка**. *Гаиләсе белән барып ял итәр өчен, шифаханәгә юллама бирделәр.* А.Нәҗми. *Бер группада укыган, бер бүлмәдә торган егетләрем берәм-берәм каникулларга таралыша, эшкә юллама алган районнарына таба таралыша башладылар.* А.Хәсәнов

2) Дөрес юлга юнәлтү өчен бирелгән үгет-нәсыйхәт, фатиха. *Миңа киң иҗат мәйданына башлап юллама биргән кеше зур талантлы шагыйрь Шәехзадә Бабич үзе булган икән!* Н.Исәнбәт. *Китапның күпчелек хикәятләре менә шундый шартларда яшәргә күнектерү, ә инде андый хәлләргә тарыганда, иленә, йортына лаеклы яшәргә юллама – юнәлеш күрсәтүгә әйләндерелә кебек.* М.Гайнетдин

**ЮЛЛАНУ** I *ф.* 1) *кайт. юн. к.* **юллау** I. *Владимир каласына икенче мәртәбә юлланган Дәүләтьяр кайтып төште.* В.Имамов

2) *төш. юн. к.* **юллау** I. *Бу хат бүгенге бөтен татар язучыларына да юлланган бит.* М.Вәли-Барҗылы. *Рәнҗешләрнең кайда һәм ни өчен юллангасын карчык белә иде.* М.Кәбиров

3) *диал.* Берәр якка китү; юлга чыгу, сәфәргә юнәлү. *Хәйбулла, сызгырына-*

*сызгырына, абзар ягына, малларын карарга юлланды.* Ш.Камал. *Июнь азагында Уфага юлланды Зөбәрҗәт, нәнәсе аны урамга чыгып озатып, таягына таянган килеш, күздән югалганчы карап калды.* Х.Мөдәррисова

**ЮЛЛАНУ** II *ф.* Юл-юл булып тору, юллар ясалу. *Былтыр су коендырып кайткач, йонының өстендә кояш уйнап йөри торган, сыртлары беленми торган атларның да кабыргалары юлланып, саналып тора.* Г.Исхакый. *Тулган айдан нурлар агла ак көмештәй юлланып, Күрнә кырлар һәм дә таулар, балкып, иркен, моңланып.* Н.Исәнбәт

**Юлланып тору** Әле, хәзерге вакытта юлланып күренү. *Кыш көне болытлар юлланып торса – аязга.* Сынамыш

**ЮЛЛА́У** I *ф.* 1) Кая булса да җибәрү, озату. *Атабай мордарны дарга элеп куясы урынга Нугайга юллап, Мәскәүгә качырды.* Р.Батулла. *Аннары Хәмбәл күбесенчә суварлылардан хасил ике мең газине Саксин каласына юллады.* В.Имамов

2) Күндерү, җибәрү, тапшыру. *Котылулары өчен изге бөек аллаларга рәхмәт юллап җиргә егылдылар.* Н.Фәттах. *Җәлладлар хасил булган очракта, елдам хәбәр юлларга онытмагыз...* В.Имамов

3) Юнәлешне күрсәтү, юнәлтү. *Ул арада кара киемле, караңгы чырайлы, телсез надзирательләр, ым белән генә юллап, мине тар тимер баскычлардан төрмәнең югары катына алып менеп киттеләр.* И.Салахов

**Юллап тору** Һәрвакыт, гел, даими юллау. *Һәрбер сәрдар биш көн саен солтан галиҗәнаплары тарафына чапкын юллап тора.* В.Имамов

**ЮЛЛА́У** II *ф.* 1) Юл йөрү, юл үтү. *Хатыннар, көянтә-чиләкләрен асып, ат эчерергә суга йөгерәләр. Монда да үзенә күрә ярыш ---. Кая инде Гөлбануга җитәргә! Мәгъмүрә бер юллаганчы икене китерә, бер басканчы өчне баса!* Казан утлары

2) Үтәргә мөмкин булган урынны табу, юл табу. *[Партизан] Күкрәк ярасын Кысып тоткандыр, Ә шулай да кан Бармак арасын юллап аккандыр.* Ш.Маннур

3) Үтенеч белән мөрәҗәгать итү, нәрсә дә булса сорау. *Спектакльләр куйдыру өчен, Даут бәй жандрам идарәсеннән рөхсәтләр юллап, оештыру эшләрен оста эшли торган булып китә.* Р.Батулла. *Чөнки тәрәзә йөзлекләре юллап килүчеләр әледән-әле үзләренең кем улы, кем кызы һәм кайсы тармактан, кайсы чыбыктан Гыйлемханнарга кардәш тиешлекләре турында да җиткерергә онытмыйлар иде.* Р.Мөхәммәдиев

4) Кемне яки нәрсәне дә булса эзләп табу, эзләп йөреп булдыру, хәстәрен күрү. *Икенче көн иртән иртәрәк торып, [Габдерәүф] завферманы юллап китә.* К.Кара. *Райбашкармага барып, өй салдыру өчен, агач юллап кайттым.* В.Нуруллин

5) Таләп итү, даулау. *Без тик, сезнең битлекләрне ертып, Тыныч яшәү хакын юллыйбыз.* Ә.Ерикәй

**Юллап бетерү** Тулысынча, барысын да юллау. *Йомышларын көнендә юллап бетерә алмасалар, безгә кунарга керәләр.* А.Хәсәнов

**Юллап йөрү Әле, хәзерге вакытта юллау.** *Тегенең йомыш юллап йөрүе кыяфәтенә чыккан.* А.Гыйләҗев

**Юллап карау** Юлларга омтылу. *Сине 1938 елдан белгәнгә күрә, үз җаваплылыгым астында, Төркиягә барырга рөхсәт юллап карармын.* З.Хәким

**Юллап тору** Һәрвакыт, гел, даими юллау. *Тирәкләрнең җиргә кадәр иелгән ботаклары рәхимлек, шәфкать, мәрхәмәт юллап торганы --- һәркемгә күренә.* Б.Рәхимова

**ЮЛЛЫ** *с.* 1) Юллар сызылган, сызыклары булган. *Аның киң нурлы йөзе, бик аз чал кергән түгәрәк сакалы, кара юллы ак чапаны, бик шомалап чалган һәйбәт чалмасы, ничектер, һәммә кешедә җылы бер илтифат уйгаттылар.* Г.Ибраһимов

2) Юл салынган, йөрерлек хәлдәге юлы булган. *Көнгә ничәшәр мәртәбә аның күз алдына килә ич ул такыр таш урамлы, карсыз, чиста юллы, кешеләре һәрдаим базар көндәй гөҗләп торган шәһәрчек...* Л.Хәмидуллин

3) Алда күрсәтелгән санча юллары булган. *Бу очракта мин дүрт юллы халык җырының никадәр күп хикәя сюжеты тудыра алу көченә-кодрәтенә, аның киң иңле, озын буйлы һәм тирән эчтәлегенә басым ясарга тырыштым.* М.Хуҗин

4) *куч.* Юньле, җайлы, ипле. *Гатаулла абзый болай бик әйбәт, юллы, ипле кеше иде.* Ш.Еникеев

**ЮЛЛЫК** I *и.* **1.** 1) Юлга, сәфәргә билгеләнгән акча һ.б. нәрсәләр. *Эченнән: «Бу мөсафир инде өенә кайтырга юллык өчен миннән бераз ярдәм сорый торгандыр», – дип уйлады.* Г.Камал

2) *иск. этн.* Кәләш янына кияү булып килгән кешедән сорап алына торган бүләк, күчтәнәч. *Кияү юллыгын гына күбрәк ал!* Г.Исхакый

**2.** *с. мәгъ.* Юлга җитәрлек, юлга билгеләнгән. *Соңгы сүзне Василий Фомич әйтә: – Кем теле – бәйләп тотучы юк, юллык ризык та алсыннар.* А.Тимергалин. *Олы абый, онытмагансыңдыр, сугыш беткән елларны сәфәрләреңне мин дә хуплый идем. Юллык акча биргән чакларым да булды.* А.Гыйләҗев

**ЮЛЛЫК** II *с.* Билгеле юллар эченә сыеп бетәрлек яки билгеле сандагы юллардан торган. *Витя, мендәре астыннан газета чыгарып, дүртенче биттәге бик вак хәрефләр белән җыелган ун юллык мәкаләне күрсәтте.* Г.Әпсәләмов

**ЮЛЛЫК** III *и.* Мич куышлыгыннан морҗага кадәр булган төтен юлы. *Төтен алга килми, ялкын да, артка кайтарылып, мич көймәсен ялмап, юллыкка кереп китә иде.* Казан утлары

◊ **Юллыкка кычкыру** Төтен юллыгына кычкырсаң, Тәңрегә ирешә, имеш, дигән ышану нигезендә барлыкка килгән ырым: берәр кадерле, изге теләгеңне яисә үлү-туу хәбәрен юллыкка әйтү. *Хәзер аның әнисе коймак пешерәдер, юллык тишегеннән табагачын сузган да: «Вәлишә бәпкәм, кайт, коймак пешердем», – дип кычкырадыр.* Т.Гыйззәт

**ЮЛЛЫК** IV *и.* Идәнгә җәелә торган озынча келәм, палас. *Зәңгәр һәм кызыл төстәге бик йомшак юллык түргә хәтле үк җәелгән.* Т.Нурмөхәммәтов

**ЮЛЛЫ́-ЮЛЛЫ** *с. к.* **буй-буй**. *Шәльяулыгым юллы-юллы, Ник ташладым юллы дип?!* Җыр. *Кояшка, айга күрсәтми торган юллы-юллы капчыкны [озын күлмәкне] татар кызына да бирделәр.* Ф.Әмирхан

**ЮЛЛЫ́-ЮЛСЫЗ** *с.* **1.** Юлы кайда булган, кайда булмаган, сирәк йөрелгән, аз тапталган, юлы начар булган. *Күп йөрдем мин сугыш кыры буйлап Юллы-юлсыз урман-аланда.* Ш.Маннур

**2.** *рәв. мәгъ.* Юл сайлап тормыйча, кайда юлдан, кайда юлсыз. *Юллы-юлсыз бара торгач, чытырман эчендә җиргә иңеп утырган бер йортка килеп җиткән.* Әкият

**ЮЛСЫЗ** *с.* **1.** 1) Юлы булмаган, юл салынмаган. *Юлсыз җирдән саз ерып барырга туры килде...* В.Гали

2) Юл өзелгән, йөрерлек булмаган. *Вакыйгаларның 1773 елның зәһәр салкынлы кышкы, юлсыз айларында баруын да, башкорт каһарманының*

*[Салават Юлаевның] бу вакытта яралы булуын да – һәммәсен исәпкә алу кирәк иде.* В.Имамов. *Табигатьнең карлы-буранлы, җилле-яңгырлы юлсыз көннәрен җиде яшьлек сабый җилкәсе күтәрергә, сынатмаска, чыдам булырга өйрәнгәндер.* Г.Шәйхи

3) *күч.* Юлдан язган, азып-тузып йөргән, бозык. *Юлсыз адәмнәргә Тугрылыкны һаман өйрәттем.* Г.Сөнгати

4) *күч.* Сөйләмендә һәм гамәлләрендә эзлеклелек булмаган, итагатьсез, тәрбиясез. *Ул кеше әйтте: – Бу нинди юлсыз сүз?! Бу нинди ярамас эш? Мин яхшылык итеп сине уттан тартып чыгардым, син мине чагарга телисеңме?* Ибн әл-Мөкаффагъ

**2.** *рәв. мәгъ.* Юлдан башка, юл эзләп тормыйча. *Тагы шундый ук юлсыз, сукмаксыз барып, авылның читенә җитте.* Г.Ибраһимов. *Җилгә каршы юлсыз атладым.* Казан утлары

**3.** *и. мәгъ.* 1) Юлдан чыккан, юлын югалткан кеше. *Мәрхүм әбисе әйтә иде: «Һәр сөюнең үз йолдызы бар. Адашканнарга, юлсызларга шул йолдыз юл күрсәтә», – ди торган иде.* Г.Гыйльманов

2) Азгын, законга, кабул ителгән тәртип-кагыйдәләргә буйсынмый торган кеше. *[Аксәет Идегәйгә:] Остаз хакын таптадың! Мал бастың, җыен азган-тузган, җыен юлсызга баш булдың.* Н.Исәнбәт

**ЮЛСЫЗЛЫК** *и.* 1) Юллар булмау, юл салынмау хәле. *Балачакта иң үзәккә үткәне – юлсызлык --- авылга кайту һәм кире китә алмыйча газапланулар булды.* Р.Миңнуллин

2) Юл төшмәгән чак, юл өзелгән вакыт. *Буран басылса да, юлсызлык җанга тия башлады.* Р.Батулла. *Озакламый кыр-калкулык һәм чокыр-чакырлыклар, кар катыш пычракка батты һәм юлсызлык башланды.* Ш.Шәйдуллин

3) *күч.* Чарасызлык, билгесезлек, аптыраш. Бу авыр хәлдән, бу *юлсызлыктан чыгуда төп ярдәмчем Гаяз булды.* М.Әмир

4) *күч.* Азгынлык, бозыклык, начар юл. *Без, Мансур агай, надан, кара халык. Без монда шул каралык белән сугыштан куркып кына җыелган идек, ә соңыннан, үзебез дә белми, юлсызлыкка кереп киттек.* Һ.Такташ. *Ә цивилизациялелектән читенү, торгынлык черүенә чумып потрыклану бездә кешелектән маймыллыкка кайту юлсызлыгына чыгуны хәтерләтә.* М.Гайнетдин

**ЮЛТЫЙ** *и. диал.* 1) Төрле шикле юллар белән бәхет эзләүче, авантюрист. *Юлтый юлламый торса, күңеле булмый.* Мәкаль. *Юлтый үз үлеме белән үлми, ди.* Мәкаль

2) Көтмәгәндә уңышка, очраклы бәхеткә ирешкән кеше

**Ю́ЛЧА** *рәв.* 1) Юлда йөргәнчә, юлга чыккан кешеләрчә. *Тегендә, өй ишегe төбендә, бөтенләй юлча киенеп, толыпларда, шарф, пималарда ак сакаллы карт кода Шибай күренде.* Г.Ибраһимов

2) Рәвешчә, чара, юл белән, мөмкинлек табып. *Акылы да, олы галимлекләр Бүтән юлча килә белмәдә.* Ф.Яхин

**ЮЛЧАБАР** *и. иск.* Боерык, әмер һ.б. берәр төрле хәбәрне ерактагыларга җиткерү өчен җибәрелә торган чапкын. *Юлчабар ук кебек атына менеп тезгенне кагуга, аның түм-түгәрәк юргасы күздән югала.* Ш.Әхмәдиев

**ЮЛЧЫ** *и.* Кая да булса барырга чыккан кеше, юл кешесе. *Авылдан чыгып, ике-өч чакрымнар киткәч, аны атлы-арбалы бер юлчы куып җитте.* Г.Гыйльманов

**ЮЛЫ** *бәйл. сүз* Мәртәбә, тапкыр, кат. *Бер үк дәрьяга ике тапкыр керә алмыйсың, чөнки һәр юлы, сине ягалап, яңа сулар ага.* А.Тимергалин. *Икенче юлы сабак булыр...* А.Гыймадиев

**ЮЛЫГА** *бәйл. сүз к.* **юлы**. *Ярый, ул хакта сүз тәлинкәсен әйләндерүне икенче юлыга калдырып торыйк.* Ф.Яхин. *Бу юлыга эшендәге хаталары өчен Закировка каты шелтә бирү җитәр дип уйлыйм.* Г.Галиева

**ЮЛЫГУ** *ф.* 1) Берәр кешегә яки берәр нәрсәгә очрау, туры килү. *Тамчыдан качкан явымга юлыгыр.* Мәкаль. *Яман белән юлдаш булсаң – ярга егылырсың, яхшы белән юлдаш булсаң – малга юлыгырсың.* Мәкаль. *Юлда барганда, бер Гамир атлы гарәп юлыгып, боларга юлдаш булды.* К.Насыйри

2) Берәр хәлгә тап булу, эләгү, тару. *Ленар, әрәмәлектән каршына бормаланып төшеп килгән бу тасмага карап, дөресрәге, аның сихри-зәхмәти шаукымына юлыгып, баскан урынында катты да калды.* Г.Гыйльманов. *Кеше хакына керү барыбер кайчан да булса фаш ителә һәм харам җыйган барыбер казага юлыга.* М.Мирза

3) Кагылып узу, юл уңаена кереп чыгу. *[Миләүшә] Базарда булды, кайтышлый гастрономга керде, икмәк кибетенә юлыкты.* И.Гази

4) Барып җитү, адресат кулына керү (мәс., хат). *Мәгълүм булсын, гыйнварның унында сиңа хат язган идем, шаять, юлыгып алгансыңдыр.* Ш.Мөхәммәдев. *Җавабән язган хатың юлыкты.* Ш.Әхмәдиев

**Юлыга бару** Торган саен ешрак юлыгу. *Балигъ булмаганнар эше буенча комиссия утырышларында мондый хәлләргә елдан-ел күбрәк юлыга барабыз.* Маяк

**Юлыга башлау** Юлыгырга тотыну. *Нишләптер аның әле яңа ярылган бөре кебек кенә гомере инде төрле ярамыйларга юлыга башлады.* З.Мурсиев

**Юлыгып кую** Кинәт юлыгу. *Йөри торгач, бәлки, Мусаның дәфтәрендә күрсәтелгән кешеләрнең берәрсенә яки аларны белгән кешеләргә юлыгып куяр.* Г.Әпсәләмов. *Хатыныңны мөселман диненә күчереп, муенындагы тавык тәпиен алып ташламасаң, яман хәлләргә юлыгып куюың бар.* М.Хәбибуллин

**Юлыгып тору** Һәрвакыт, гел юлыгу. *Корабның – илнең җил-давылларга юлыгып торуының шаһиты – лирик герой – киләчәккә ачынып карый.* Т.Галиуллин

**ЮЛЫГЫШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **юлыгу**. *Ахыр, бергә-бер юлыгышып, каты орыш кылдылар.* Әкият

2) *к.* **очрашу**. *Алар [Баязит белән Давыт] бергә туып, бергә үйнап үстеләр, байтак еллар аерылып яшәгәннән соң, менә бу ел тагы юлыгыштылар.* Г.Ибраһимов

**ЮЛЫК** *и. иск.* Оныкның оныгы. *Чулыклары [тырыша] белмәгән икән, без юлыкларга тырышу кирәк иде.* Р.Фәхретдинов

**ЮЛЫКТЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **юлыгу** (*1, 3 мәгъ.*). *Рәшитнең җитди сынаулары самолётка утыру белән тәмамланмый, автор аны ачы буранга юлыктырып, үлем белән күзгә-күз очраштыра.* Татар әдипләре

2) Юнәлтү, юнәлеш бирү, берәр юлга кертеп җибәрү, юлату. *Дусны – үзгә, дошманны (ялган) эзгә юлыктыр.* Мәкаль

3) Дучар итү. *Алар [шигырь юллары], фикер мәгънәләрен читкә куймыйча, укучыны ык-мыкка юлыктырып азапламый, аны тотлыктырмый, гомумән, сокланырлык дәрәҗәдә төзек, ыспай итеп язылган.* К.Гыйззәтов. *«Хөррият этабы» мәдәни яңарышы көннәрендә, йөз илле еллар, царизм бууы чиренә юлыктырып, буып тотыл-*

*ган газетачылык эшен заманча югарылыкта эзгә салу бурычы күз алдына калка.* М.Гайнетдин

4) Бергә итү, кушу, кавыштыру. *Кызның яры кырыктыр, Ише чыкса – юлыктыр.* Мәкаль

**ЮЛ-ЮЛ** *с.* **1.** Буй-буй, юллы, сызыклар төшкән, тасмалар сузылган. *Тегермән дамбасы өстендә киң кара фуражка кигән мәһабәт бер ир күренде. Күкрәгендә – юл-юл тельняшка.* Казан утлары. *[Өстендәге] Юл-юл күлмәкләр, сырган телогрейкалар арасында аның --- кара ефәк жилеты сөлек сырты кебек ялтырый иде.* Казан утлары

**2.** *рәв. мәгъ.* Буй-буй булып, тасмалар рәвешендә. *Тау битендә юл-юл җәелеп ята Иген кырлары.* Һ.Такташ

**ЮЛ-ЮЛЛЫ** *с. к.* **юл-юл**. *[Мырауҗанның] Чалбарыдыр буй-буйлы, Камзулыдыр юл-юллы.* Н.Исәнбәт

**ЮМА** *с. к.* **юмакай**. *Бу карт дөя һичшиксез егылачак, озакламый егылачак. Егылган кара нарны хуҗасы кыйнап та карар, юма сүзләр дә әйтер. Ләкин дөя тормаячак.* Р.Батулла

◊ **Юма тел** Юмаларга оста булган, йомшак, ягымлы сөйләшә торган кеше. *Түрфәндә чыркылдап көлеп җибәрде. – Сиңа ихахай да михахай, юма тел үзеңдә, – дип, Фаяз ризалыгын белгертеп кулын селтәде.* Х.Камалов. **Юма телләнү** Ягымлы итеп, кемгәдер ярарга тырышып сөйләшү. *Китек каш «йолдызлар да көнләшәдер әле сездән» дип, бик юма телләнеп, сөйләнеп бара.* Р.Төхфәтуллин

**ЮМАГАЙ** *с. к.* **юмакай**. *Шушы тынлыкта сыек зәңгәр күзләре куерды, ачулы йөзе юмагай елмаюга алышынды.* К.Кәримов. *Бу юлы укытучылар бүлмәсендәге телефоннан аның йомшак, юмагай, ипле тавышы ишетелми...* Казан утлары

**ЮМАКАЙ** *с.* **1.** 1) Ягымлы, йомшак, юмалый торган. *Идел буе Болгары ханы Алмас, хәлифәнең юмакай сүзләренә алданып, ислам динен кабул итә. Әйе, хәйләкәр хәлифә аңа тау-тау алтын вәгъдә итә.* М.Хәбибуллин

2) Сүз белән юмалап күндерергә оста булган, кемгәдер ярарга тырышып сөйли белгән, ялган нәзакәт күрсәткән, ялагай, ярамсак. *Юмакай чибәр кыз бер алдыңа төшәр, бер янга килер, Көйләр сине, йомышы төшкән – эше бар.* Ш.Галиев

3) Ялагайлану белдергән, ясалма. *Бераз колак салып торуга, үгет биргән сыман сөйләүче юмакай тавышны да таныды – бу, әлбәттә, җәдитчеләр «аксакалы» Госманхуҗа иде.* Т.Әйди. *Ул тулы тыгыз битле, таза иңле, юмакай ягымлылыгы белән яктырып торган чырайлы.* Х.Камалов

**2.** *и. мәгъ.* Юма телле кеше, ялагай. *Карап торышка бик күндәм һәм беркатлы кебек тоелса да, ятимә кыз инде кемнең кем икәнен аера, юмакайларның агентына бирешми, мәкерле тәкъдимне шундук кире кага.* А.Тимергалин

**ЮМАКАЙЛАНУ** *ф.* Юмакайлык, ялагайлык күрсәтү; юмалау. *Карчык-корчыкка исле сабын, гатырша мае, яулык ише нәрсәләр өләште, дип сөйләгәннәр. Юмакайлана, ярарга тырыша, ди.* А.Тимергалин

**Юмакайланып алу** Бераз, берникадәр юмакайлану. *Әмма бу – хөкүмәтнең билгеле сәяси вакыйгалар алдыннан һәм үзе өлешеннән мәхрүм ителгән гражданнары алдында бераз юмакайланып алу гамәленә генә охшаган.* Татарстан яшьләре

**Юмакайланып йөрү** Һаман, һәрвакыт юмакайлану. *Тотынырга бер терәк тә юк ич янәшәдә! Күзләрен ышереп, тирәндә юмакайланып йөргән бәндәләр-шәүләләр генә ич бары...* Р.Зәйдулла

**ЮМАКАЙЛА́У** *ф. к.* **юмалау**. *«Һиммәт иясе» дигән булып юмакайлавыңнан тел төбең кая барганлыкны аңлыйм.* Ш.Камал

**Юмакайлый башлау** Юмакайларга керешү. *– Документларсыз ул үнәрләр начар була, – дип юмакайлый башлады.* Татар әдипләре

**ЮМАКАЙЛЫК** *и.* Юмакай булу сыйфаты. *Әүвәл икеләнеп утырган Бәхтияр хәйләкәр байның юмакайлыгына хәзер инде тәмам ышана.* Т.Әйди

**ЮМАЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **юмалау**. *Айдар үзенең Казан дошманы булуын белдереп, Казанны алуы илә Иванны котлады исә дә, аның бу юмалանулары Иванны йомшартмады.* Һ.Атласи

2) Иркәләнү. *– Әбекәем, бәгырем, – диде, балаларча юмаланып, – без кайтуга өй җылы булыр бит?* Ә.Еники

3) Юану, нәрсә белән булса да мавыгу. --- *транзистордан талгын музыка моңы агылды, һәм алар [егет белән кыз], әнә шул футлярларына юмаланган хәлдә, төнге Идел өстендә көймәдә тибрәлгән бүтән җаннар турында татлы да, ачы да уйларга чумдылар...* Казан утлары

**Юмалана бирү** Юмалануын һаман дәвам итү

**Юмалана төшү** Бераз юмалану; тагын да ныграк юмалану. *– Чәй янына әле, бәлкем, берәр җылы аш та булыр, ә, әбекәем? – диде Рәшидә, тагы да юмалана төшеп, һәм Зөфәргә хәйләкәр генә күз кысып куйды.* Ә.Еники

**ЮМАЛА́У** *ф.* 1) Ягымлы, йомшак сүзләр әйтеп үгетләү, шул рәвешле күндерергә, ризалатырга тырышу. *Көн саен берәр сәгать аның белән азапланалар, ахырда көчкә, алай итеп, болай итеп, алдалап, юмалап, барырга күндерәләр иде.* Г.Рәхим. *Болай оста юмалауга каршы торып булмый, кулдан килсә-килмәсә дә тотынырга туры килә.* С.Сабиров

2) Кемне дә булса ялган мактау сүзләре белән алдап, хәйләләп кызыктыру, үз ягына аудару. *Ә Сәләмә – хәсрәт бәндә ул, беркатлы, аны алдалау, юмалау озак вакытны сорамый.* Р.Сибат

3) Юату, тынычландыру. *Уйнатып та, куркытып та, юмалап та карый, ләкин бала тынычланмый.* Р.Батулла. *– Чү! Кызма әле син, туган, – диде Иннокентий, аны юмалап.* З.Мәхмүди

**Юмалап бетерү** Бик нык, бөтен белгән ысулларын да кулланып юмалау, килешкәнче юмалау. *Ничек итеп кенә юмалап бетермәдем, бер кашык та ботка капмадылар.* Ватаным Татарстан

**Юмалап кую** Алдан яки кыска һәм тиз генә юмалау. *Бик оста юмалап куйдыгыз әле сез, Айдар Дамирович!* Безнең гәҗит

**Юмалап чыгу** Барысын да, һәрберсен берәм-берәм юмалау

**Юмалап тору** Һәрвакыт, гел юмалау; әле, хәзерге вакытта юмалау. *Аларны [балаларны] машинадан көчкә тартып төшерәләр дә әтә-төртә ишектән эчкә кертеп җибәрәләр, юатып, юмалап торырга вакыт калмаган, әти-әниләренең эшкә йөгерәсе бар.* Мәгариф һәм Гаилә һәм мәктәп

**Юмалый башлау** Юмаларга тотыну. *Тегеләр аны үзләренчә юмалый башладылар, – дип сөйли бирде Сабир Кәшфиевич.* Ф.Яхин

**Юмалый бирү** Һаман да юмалавын дәвам итү

**Юмалый төшү** Бераз юмалау; тагын да ныграк юмалау. *– Беләсең ич, Гыйният җаным, синең өчен янган утка керергә торуларымны. – Бу юлы йомшаграк, хәтта беркадәр юмалый төшебрәк тезде Хәмдия.* Казан утлары

**ЮМАРТ** *с. фар.* **1.** 1) Булган байлыгын кызганмый торган, саран булмаган. *Җәннәт – юмарт мөселманнарның йортыдыр.* А.Тимергалин. *Сихерле, тирән иде аның карашы, кеше җанын үтәли тишә ала торган сөрмәле күз бүләк иткән иде юмарт табигать бу егеткә.* А.Гыйләҗев

2) Алда күрсәтелгән сыйфаты югары булган. *Г. Камал театрының тамашачысы да башка театрларныкыннан аерылып тора: алар самими, хискә юмарт, рәхмәтле.* Р.Вәлиев. *Матур сүзгә юмарт, ягымлы кешеләр дә очрады.* И.Туктар

3) Күп булган, мул, бай. *Татар иле иккән юмарт иген.* Л.Шагыйрьҗан. *Рәхәтләнеп балык тотканнар, аучылык белән шөгыльләнгәннәр, шушы юмарт кул ярдәме белән көн иткәннәр.* А.Хәсәнов. *Иртәдән үләннәрне юмарт чыклар белән чылата да кыздыра башлый кояш, чыдарлык түгел.* К.Кара

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Күпләп, мул итеп. *Яз кояшы ярыйсы юмарт елмая, болай булса, озак көттермәс, кырлар да кардан арыныр.* А.Әхмәтгалиева

2) Киң күңел күрсәтеп, саранланмыйча; --- *карчык-корчыклар юнәткән ризыкларын юмарт бүлешәләр.* А.Гыйләҗев

**3.** *и. мәгъ.* Кешедән бер әйберен дә жәлләмәгән, саран булмаган кеше. *Юклык юмартның кулын бәйли.* Мәкаль. *Юмартның күләгәсе киң.* Мәкаль

**ЮМАРТЛАНУ** *ф.* 1) Юмартка әйләнү, юмарт булып китү. *Җәй кояшы, юмартланып, Нурларын сибә җиргә.* М.Яруллин. *Ания, юмартланып, үз йортыннан да тәм-том ташый.* Р.Габделхакова

2) Юмартлык күрсәтү. *Ходай Тәгаләнең шушылай юмартланып сипкән җәннәт бакчалары да булса була икән!* В.Имамов. *Көндәше юккадыр, бердәнбер булуның нәүмиз бәхетеннән арыган Кояш төннәрен, юмартланып, нурын Айга бирә.* М.Галиев

**Юмартлана бару** Торган саен күбрәк юмартлану. *Картая-картая, адәм баласы сүзгә юмартлана бара, күрсәң.* С.Поварисов

**Юмартлана төшү** Тагын да юмартлану. *Сәрбиҗиһан, аның [малайның] икеләнүен күреп, тагын да юмартлана төште.* Ф.Яруллин

**Юмартланып алу** Берникадәр, берара юмартлану. *Бер елны көз көне, Казанга солы сатарга чыгып китәр алдыннан, әти ничектер юмартланып алды.* Казан утлары

**Юмартланып китү** Кинәт юмартлану. *Мин, юмартланып китеп, Миңнисага тагын да ниләрдер бирергә җыенганда – бүлдерделәр.* Г.Бәширов

**ЮМАРТЛЫК** *и.* Юмарт булу сыйфаты. *Юмартлыгы аркасында ул [Хатәм Тай] мәңгегә рәхмәт хисе белән телгә алына торган юмартлык символы булып калган.* М.Гайнетдин. *Яр астында Аксу җәелеп ага. Язгы гөрләвекләр юмартлыгыннан ул купшылангаy, киңәйгән.* Г.Әдһәм

**ЮМАРУ** *ф. диал.* Йомарлау, учка алу; учка салып уу. *Заһидуллин җирне аяк белән баскалап, куллары белән юмаргалап карады.* Г.Иделле

**ЮМОР** *и. ингл. кит.* 1) Үзара сөйләшкәндә, матур әдәбиятта һәм сәнгать әсәрләрендә чагылган, тормышта булган көлкеле, кызык нәрсәне күрә белү, шуны мәзәк итеп көлә белү сәләте. *Монда [Туфан Миңнуллин иҗатында] җиңел, уйнак юмор, җитди көлү һәм сатирик үткенлек, лиризм һәм драматизм, фаҗига да үзара тыгыз аралашкан хәлдә яшиләр.* А.Әхмәдуллин. *Аларны тасвирлаганда, автор еш кына юмор, яратып көлү алымнарын куллана.* Ф.Галимуллин

2) Юмористик стильдә язылган әсәр. *Сурәтле сәнгатьнең сатира һәм юмор характерындагы үрнәкләре «Чаян» журналында басыла килде.* К.Гыйззәтов. *Хәер, Факил Әмәкнең юмор язу һәм бастыру мөмкинлеген беркем дә чикли алмый.* М.Вәли-Барҗылы

**ЮМОРЕ́СКА** *и. нем.* Кечкенә күләмле юмористик әдәби яки музыкаль әсәр, юмористик парча. *Бернисә елдан соң Муса агайның бу гадәтен юмореска итеп язган идем.* Р.Вәлиев

**ЮМОРИСТ** *и. рус* 1) Юмористик әсәрләр язучы әдип яки шундый әсәрләрне укучы сүз остасы. *Ул елларда сәхнәләрне сатирик Гамил Афзал белән юморист Шәүкәт Галиев тотып тора.* Р.Миңнуллин. *Мин, юморист булarак, тамашачымны көлдерергә, азга гына булса да авыр уйларыннан арындырып торырга тиешмен.* М.Кәбиров

2) *сөйл.* Юморга һәвәс кеше, мәзәкче. *Мәхмүт ага искиткеч юморист иде, китапханә залыннан ул кузгалып чыгып китүгә, без аның артыннан чыгып, аны урап алып көлке тыңлый идек.* М.Мәһдиев. *Бу кадәр юморист икәнеңне белмәгән идем, малай.* З.Мәхмүди

**ЮМОРИ́СТИК** *с.* 1) Юмор белән тасвирланган, сурәтләнгән, юмор белән язылган. *Юмористик һәм сатирик әкиятләр белән мәзәкләр арасында охшашлык бик зур.* Л.Җамалетдинов. *Ул гади тормыш күренешләрен үткен каләме аша танымаслык итеп үзгәртә, төшенчәләрне көтелмәгәнчә, юмористик рухта яңгырата.* Л.Минһаҗева

2) Юморлы нәфис әдәбиятка карый торган; шундый әсәрләр басылган. *«Чаян» журналы – Казанда 1923 елдан башлап нәшер ителгән сатирик һәм юмористик журнал.* Г.Исхакый

**ЮМОРИ́СТИКА** *җый. и. рус* Юмор белән язылган, эшләнгән әдәбият яки сәнгать әсәрләре; әдәбиятта һәм сәнгать әсәрләрендә юмор белән бирелгән моментлар. *Холкым буенча шаян кеше булганлыктан, карикатура, юмористика миңа якынрак.* Яңарыш

**ЮНАН** *и. гр. тар.* 1) Хәзерге Төркиянең көньяк-көнбатыш яр буйларында яшәгән борынгы грек кабиләсе

2) *иск. к.* **грек**. *Ләкин Аурупа халкы, гарәпләр кулында балигъ булган юнан вә руман гыйлемнәренә варис булдылар да, сабыйлыктан чыккан бу гыйлемнәрнең ысулы хакыйкыясын ачуда озак заманга мохтаҗ булмадылар, бәлки башкалар меңнәрчә елларда ирешмәгән нәрсәләргә болар ике йөз ел эчендә ирештеләр.* Г.Бубый. *Манас Кияү каласының көчәеп китүеннән, аннан ары юнаннарның һөҗүменнән курка.* В.Имамов

**ЮНӘЙТҮ** I *ф. диал.* Арзанайту. *Бәяләрне юнәйтү әлегә күренми*

**ЮНӘЙТҮ** II *ф.* 1) *к.* **юнәтү** (*1 мәгъ.*). *Ул, үзе үк чыгып, «тагын берәр юнәйтәсе урын калмадымы микән?» дигән төсле, өй тирәсен әйләнгәләп, анысын-монысын тотып, капшап йөри башлады.* Ә.Еники

2) *диал. к.* **юнәтү** (*2 мәгъ.*). *[Мәрхәбә] Шулай юнәйтеп, дүрт тәрәзәгә бу пәрдәләрне корып җибәргәч, өйгә икенче төс үк кереп киткән кебек булды.* Г.Ибраһимов. *Шул елның августында Маһибәдәрнең ике абыйсы, ризык юнәйтү максаты белән, Ярославль өлкәсенә урман кисәргә чыгып китә.* Яңа тормыш

**Юнәйтеп җибәрү** Бераз, берникадәр юнәйтү. *Шуннан мин әйттем: әнкәй әйтә, дидем, өйдә ашарга юк, берәр нәрсә юнәйтеп җибәрсен дип әйтә, дидем.* Г.Ибраһимов

**Юнәйтеп калу** Юнәйтергә өлгерү. *Ичмасам, карт көнендә үзенең дә, кар-*

*чыгының да өс-башын рәтләп, ашаучыларен бераз юнәйтеп калыр иде.* Ә.Еники

**ЮНӘЛДЕРҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **юнәлү** I. *Ходай Тәгалә үзе мине Бакалтай тарафларына юнәлдергән.* Ә.Еники

2) Карату, текәү, төбәү. *Шәмсун күз карашын аслы-өсле киштәләрдә тезелеп куелган китапларга юнәлдерде.* А.Вергазов. *Ә инде алсу күлмәк дигәндә, аны рәссамнар гына ятармый, аны бит кояш үзе дә ярата – бөтен нурларын шул тарафка юнәлдерә.* Казан утлары

3) Рухи яки иҗтимагый процессларга билгеле бер юнәлеш бирү. *Гыйлем безгә хакыйкатьне таныта, бу [рәсем вә тасвир] фәннәр[е] аны безгә мәхәббәтле күрсәтәләр, аны иң ыспай вә иң камил шәкелдә ачалар вә шулай итеп безнең кальбләребезне камиллеккә таба юнәлдерәләр.* Г.Бубый. *Форма һәм гомумән телнең аваз ягы безне мәгънәгә юнәлдерә, мәгънәләрнең күрсәткече булып тора.* Г.Алпаров

**Юнәлдерә башлау** Юнәлдерергә керешү. *Без бүген зур канәгатьлек хисе белән дәүләтнең авыл хезмәтчәннәренә, авылның инфраструктурасын һәм социаль тормышын үстерүгә зур игътибар юнәлдерә башлавын билгеләп үтәбез.* Яңа тормыш

**Юнәлдерә төшү** Тагын да күбрәк юнәлдерү

**Юнәлдереп тору** Һәрвакыт, гел юнәлдерү. *Безнең Чәшеле халкын ниндидер сихри көч саклап, изге эшләр кылырга юнәлдереп тора.* Ватаным Татарстан

**ЮНӘЛЕШ** *и.* 1) Хәрәкәт иткән як, төбәп барган тараф. *Кояшка, агач башларына, агач төпләренә карый. Әйе, болай барсаң – төньяк, болай барсаң – көньяк. Юк, ул адашмаган, дөрес юнәлеш белән бара.* Г.Әпсәләмов

2) Йөзе белән карап торган, төбәлгән тараф. *Шуны да әйтергә кирәк: югарыда телгә алынган мәчетнең кыйбла юнәлешен билгеләү безгә мөселман төзүчеләренең белем дәрәҗәсен ачыкларга ярдәм итәр иде, чөнки михрабны дөрес чыгару өчен, астрономик күзәтүләр һәм белемнәр дә кирәк.* А.Тимергалин

3) Сүз, фикер, эшчәнлекнең үзенчәлекле ягы. *Онытылган сүзләребезне кайтару – телне баетуда мөһим бер юнәлеш бит.* А.Тимергалин. *Хөкем утырышын үзе билгеләгән юнәлеш буенча көндезгә өчкә кадәр алып барды да аннан соң бер сәгатьлек тәнәфес игълан итте.* В.Имамов

4) Иҗтимагый хәрәкәттә аерым бер тенденция. *Гомумән, француз мәгърифәтчеләренең нәфасәттәге карашлары социаль һәм сәяси юнәлеш тотуы белән характерлы.* К.Гыйззәтов. *Уральскида К.Мотыйгый редакторлыгында демократик юнәлештәге, татар телендә беренче айлык рәсемле сатирик журнал – «Уклар» чыга башлый.* Казан утлары

5) Әдәбият-сәнгать өлкәсендә агым, төркем. *Ш. Камал – совет әдәбиятында барыннан да бигрәк катлаулы чынбарлыкны тасвирлауда реализм юнәлешен үстерүе белән танылган әдип.* К.Гыйззәтов. *Р. Кутуй шигырьләрен һәм кайбер әсәрләрен футуризм юнәлешендә яза.* Идел

6) *лингв.* Фигыльләрдә эш-хәлнең субъектка мөнәсәбәтен белдерә торган грамматик категория. *Татар телендә фигыльнең биш юнәлеш формасы бар: төп юнәлеш, төшем юнәлеше, кайтым юнәлеше, уртаклык юнәлеше, йөкләтү юнәлеше.* Ф.Хисамова

7) *хәрби* Һөҗүмгә баручы гаскәрнең төп хәрәкәт итү сызыгы. *Гомуми юнәлеш, иптәшләр, бер – Берлин.* Г.Әпсәләмов. *Кутузов Бородино бәрелешендә исән калган гаскәрен, Мәскәүдән чыккач, көньяк-көнбатыш юнәлешендә алып китеп, Тарутино каласы янында хәрби лагерь төзеп туктата.* З.Зәйнуллин

◊ **Юнәлеш алу** 1) Нинди дә булса тарафка юнәлеп китеп бару. *Күп тә узмады, вертолёт, пыр-пыр килеп, һавага күтәрелде. Студентлар килгән якка юнәлеш алып күздән югалды.* А.Хәсәнов; 2) Эш билгеләнгән тәртиптә, билгеле эзлеклелектә бару. *Югалган коралларны эзләү эше әлеге вакыйга нигезендә яңа юнәлеш алырга тиеш иде кебек.* И.Хуҗин. **Юнәлеш бирү** 1) Бару юнәлешен билгеләү. *Каек аларга [ташларга] бәрелеп челпәрәмә килә дигәндә генә, Савушка үзенең озын колгасы белән аңа икенче юнәлеш биреп өлгерә.* Г.Әпсәләмов; 2) Билгеле бер максатка, карашларга юнәлтү; барышына йогынты ясау, тәэсир итү. *Безнең бабаларыбыз, татарлар, иҗтимагый-сәяси вакыйгаларны битараф төстә күзәтүче булмаган, ә бәлки бу гөрелтеле вазгыятьнең үзәгендә кайнаган. Алай гына да түгел, аларга билгеле бер күләмдә юнәлеш биргән, еш кына хәрби хәрәкәтләрнең дилбегәсен үз кулында тоткан.* В.Имамов. **Юнәлеш килеше** *лингв.* Татар телендә грамматик күрсәткече -га/-гә (-ка/-кә, -а/-ә) кушымчасы булган, эш-хәрәкәтнең юнәлешен белдереп килә торган өченче килеш. *Җөмләдә фигыль яки башка сүз төркемнәре белән мөнәсәбәткә кереп, юнәлеш килеше урын, вакыт, сәбәп, максат мөнәсәбәтен белдерә, юнәлеш килешендәге исем еш кына бәйлекләр белән ачыклана, топрыклы сүзтезмәләр, тезмә сүзләр ясалышында катнаша.* Ф.Хисамова

**ЮНӘЛЕШЛЕ** *с.* 1) Конкрет һәм даими юнәлеш белән бара торган. *Юнәлешле хәрәкәт яки процесс булсын өчен, кайчакта аны барлыкка китерә яки туктата алырлык сәбәп булырга тиеш.* Фән һәм Татарстан

2) Билгеле бер юнәлеше булган, эчтәлеген билгеләгән. *Әдәби-мәдәни юнәлешле, Чаллы халкы кич ял иткәндә укырга тиешле кушымта булганга күрә, аңа исемне «Чаллы кичләре» дип куйдым.* З.Мифтахов. *Татарстан Дини нәзарәтенең ТР Язучылар берлеге ярдәмендә оештырылган «Таян Аллага» исемле дини юнәлешле шигърият бәйгесенең нәтиҗәсе булды ул.* Ислам – Татарлар һәм мөселманнар

3) Максатчан. *Узган гасырның 70–80 нче елларында «Якты юл» колхозы специальләшеп, таналарны юнәлешле үстерү буенча уңышлы эшләде.* Г.Мөхәммәтшин

**ЮНӘЛЕШЛЕЛЕК** *и.* Билгеле бер юнәлешле булу; максатчанлык. *Республика бюджетының социаль юнәлешлелеген алга таба саклап калу түбәндәге чараларны тормышка ашыру нигезендә хәл ителәчәк.* Ватаным Татарстан

**ЮНӘЛТҮ** *ф.* 1) Юнәлдерү (*1, 3 мәгъ.*). *Малай, дулкынлануын басарга тырышып, чак кына аскарак төште дә яктылык көлтәсен мәгарә авызына юнәлтте.* А.Тимергалин

2) Төбәү, текәү, карату. *Ул [әнисе], карашын ерак офыкларга юнәлтеп, улына аңлатырга керешә.* А.Хәлим

**Юнәлтә башлау** Юнәлтергә тотыну. *XIV гасырның икенче яртысыннан Идел буе төрки шигърияте, үзенең позициясен активлаштыра төшеп, тормышның комик якларына да игътибар юнәлтә башлый.* Н.Хисамов

**Юнәлтә төшү** Тагын да ныграк юнәлтү. *Юбилее уңаеннан Радик Фәизовның иҗатына кабат күз салганда,*

*мин аның хикәяче булуына игътибарымны юнәлтә төштем.* Казан утлары

**Юнәлтеп алу** Кыска вакытлы, сирәк-сирәк юнәлтү. *Кияү егетнең күңеленә ачкыч табарга теләгәндәй, әледән-әле аңарга үзенең ягымлы һәм җылы карашын юнәлтеп ала иде.* Р.Мөхәммәдиев

**Юнәлтеп кую** Кинәт юнәлтү. *Кызыклы итеп сөйләү сылтавы белән, этик-әхлакый мәсьәләләргә игътибар юнәлтеп куя.* Р.Абдуллина

**Юнәлтеп тору** Һәрвакыт, гел юнәлтү. *Язмышны бернинди канунга буйсынмаган гигант көч туктаусыз төрле якка борып юнәлтеп тора.* Казан утлары

**ЮНӘЛҮ** I *ф.* 1) Билгеле бер юнәлешкә карап китү. *Таймас, чирәмлекне кыйгачлап кистереп, олы юлга чыкты һәм, эре-эре атлап, Хутор урманына юнәлде.* А.Тимергалин. *Бу сүзләрдән соң 16–17 яшьләрендә булган тракторчы Шәкүр, телеграф баганаларын маяк урнына кулланып, авылга табан юнәлеп китте.* В.Ильясов

2) Күз, караш белән төбәлү, текәлү, йөзен билгеле якка бору, карату. *Хәзрәт сәфәр догасына әзерләнде; Зөләйха абыстай биргән кечкенә мендәрне идәнгә салды да, үзе, --- кыйблага таба юнәлеп, шул мендәргә тезләнде.* Г.Ибраһимов. *Җир өстеннән күккә юнәлгән прожектор утлары, яктылык кайчылары булып, караңгылыкны телгәли башлады.* Ф.Хуҗин

3) *күч.* Сүз, фикер, уй, вакыйга, эшхәл билгеле, конкрет юнәлеш алу, игътибар мәгълүм нәрсәгә төбәлү. *Шулвакытта ул, файдалы эшләргә юнәлеп һәм голүм вә мәгариф белән ләззәт алып, игелекле вә бәхетле буладыр.* Г.Бубый. *Чәрелди-чәрелди очкан акчарлакларга, яр кырында чөкердәшкән карлыгачларга карап тора-тора да онытылып китә, уйлары еракка-еракка, хыялый киләчәккә юнәлә.* М.Хәбибуллин

**Юнәлә башлау** Юнәлергә тотыну. *Кол Гали кабат торткыннар арбасына юнәлә башлагач кына, ниһаять, гүзәл Сәүлия дә күңелендәге хушлашу сүзләрен тезеп салды.* В.Имамов

**ЮНӘЛҮ** II *ф. диал.* 1) Рәтләнү, юньгә килү, тәртипкә керү. *Тик аларда бераз юнәлеп, җылы аш ашап чыгу бик азларга гына тәти.* Кызыл таң

2) Савыгу, сәламәтләнү, терелү. *Һай, йөрәгем ярдың, балам. Юнәл тизрәк, авыр яраң.* Н.Исәнбәт

**ЮНӘТҮ** *ф.* 1) Бозылганны төзәтү, ремонтлау, тәртипкә китерү. *Карт исә рәхмәт йөзеннән я ава башлаган коймаңы торгызып китә, я сарай ишеген юнәтә.* М.Һудин. *Яшь хуҗа, бер лабогрейка, бер иске комбайнны юнәтеп, ашлыкны түкми-чәчми җыеп алуга ирешә.* Р.Зарипов

2) Тырышып кайдан булса да табу, табыштыру, булдыру, бар итү. *Фәтхулла хәзрәт исә, вакытлы белешмә юнәтеп, Яңа Казан Физика лабораториясенә гади электрончы сыйфатында эшкә урнашты.* А.Тимергалин. *[Габдерәүф] Булган киемнәрен тәртипкә китереп, бераз күчтәнәчләр юнәтеп, туган авылына ашыкты.* К.Кара

3) *күч.* Берәр эшне, мөнәсәбәтләрне рәтләү, җайга салу, холыксыз кешене җайлау. *[Исмәгыйльгә кияүгә чыгарга] Риза булган булып, эшне чак юнәттем.* М.Фәйзи

**Юнәтә башлау** Юнәтергә керешү. *Тора-бара ялгыз карчыкларның бәрәңге бакчасында эшләп, үзләренә дәфтәр, каләм ише уку әсбаплары юнәтә башлагач, Гөлмәрьям сөенеп туя алмады.* Ф.Абдуллин

**Юнәтеп йөрү** Әле, хәзерге вакытта юнәтү. *Әнә ул алъяпкыч итәкләрен билбавына бөреп кыстырган да тавык-чебешләренә җим юнәтеп йөри.* Г.Гыйльманов

**Юнәтеп кую** Алдан юнәтү. *Авыл кешеләре, Госман кайтканчы ук, итәкчабуларын җыеп куйдылар: кем ишек-капкасына гомер булмаган келәсен элде, кем иске мылтыгын карап, юнәтеп куйды, яисә, бер дә булмаса, таяк-тәпәч әмәлләп, ишек катына урнаштырды...* Г.Гыйльманов

**Юнәтеп тору** Һәрвакыт, гел юнәтү. *[Фәһметдин абый] Счетовод булып эшли башлаган, әнисенә ара-тирә такта чәен, шикәрен юнәтеп торган.* В.Нуриев

**ЮНӘЮ** I *ф. сөйл.* 1) Авырудан терелү, савыгу, сәламәтләнү

2) Рәтләнү, әйбәтләнү, яхшыру. *Дәүләтнең кесә ягы бераз юнәйсә, яшь урманнарны күбрәк утырта башларлар.* З.Мурсиев

**Юнәеп килү** Соңгы вакытта, бераз юнәя башлау

**Юнәеп китү** Юнәюгә таба бару. *[Әби] Үзенчә мәтрүшкәсен-ниен эчкәләп ятып караса да, бер дә юнәеп китә алмый.* Ә.Еники

**Юнәеп бару** Акрынлап, аз-азлап юнәю. *Рухи савыгып, юнәеп баруына куанып, аны тагын да үсендереп, юатасы килеп китте Әлфиснең.* Казан утлары

**Юнәя башлау** Юнәюгә табан үзгәрү. *Әкрен генә халыкның көнкүреше юнәя башлады, электр утлары кабынды, колхозчылар хезмәт көненә иген ала, күп булмаса да, акчасын да бирә башладылар.* Өмет

**Юнәя төшү** Бераз юнәю; тагын да юнәю

**ЮНӘЮ** II *ф. диал.* Арзанаю. *Ярминкәдә бал бәясе көзге вакыттагыдан нык юнәйде.* Безнең Чирмешән

**ЮНГА** *и. голл. диңгез* Суднода хезмәт итә, диңгезчелек эшен үзләштереп, матрос булырга әзерләнә торган өйрәнчек яшүсмер. *Керчь белән Севастополь арасында йөргән паром палубасына юнга булып уналты яшемдә баскан идем.* А.Хәсәнов

**ЮНГШТУРМ** *и. нем.* 1) *тар.* Германиядә XX гасырның 20–30 нчы елларында фашизмга каршы көрәшүче коммунистик яшьләр оешмасы

2) *күч.* Коммунизм идеяләре өчен көрәшкә чыккан яшь кеше. *Безнең исем – батыр юнгштурм, Яшь ударник, җитез коммунар.* М.Җәлил

3) *күч.* XX гасырның 20–30 нчы елларында комсомоллар кигән ярымхәрби стильдәге кием. *Үзара исәнләшә торган арада залга юнгштурм костюмы – өстенә күн тужурка, аягына гетрлар кигән Фатих Хөсни килеп керде дә ишек төбендә тукталып калды.* Казан утлары. *Кап-кара сумала белән катырган көймәдә җитен чәчле, юнгштурм киемле Рәхми дигән журналист егет белән шигырь тирәсендә чуалучы Ишбай утырган.* Казан утлары

**ЮНГЫ** *и.* Юнып алынган кисәк. *Мал – җанның юнгысы, бала – тәннең юнгысы.* Мәкаль

**ЮНКЕР** *и. нем. тар.* 1) XIX гасырга кадәр Германиядә җирбиләүче, авыл дворяны, алпавыт

2) 1918 елга кадәр Россиядә: хәрби мәктәп укучысы; курсант; офицер чины алырга әзерләнгән түбән чинлы хәрби. *Һәм гимназия белемле, студент та булып өлгергән егетне Петропавловск хәрби юнкер училищесына әфисәрлеккә укырга җибәрәләр.* З.Зәйнуллин

**ЮНУ** *ф.* Нинди дә булса каты нәрсәнең кырыен яки өстен телемнәр ясап телеп алу, шул юл белән ни дә булса ясау. *Саргылт комташтан юнып ясалган кабер ташы кара туфрак өемендә күзгә бәрелеп тора.* А.Тимергалин. *Ра-*

*шат, Луизаны бер кырыйгарак кагып, өстәл тартмасын ачты һәм аннан яргаланып, тузып беткән, пәке белән юнып ясалган өч тәгәрмәчле арба тартып чыгарды.* А.Гыйләҗев

**Юна төшү** Тагын да бераз юну

**Юнып алу** Тиз-тиз генә бераз юну

**Юнып ату** Тиз-тиз, аннан-моннан юну. *Бабасы бер шаккатсын – Шушы агачны Габделхәй Тиз генә юнып атсын!..* Г.Әпсәләмов

**Юнып бетерү** Тулысынча, ахырга кадәр юну. *Урыны-урыны белән кабыкларын да юнып бетермәгәннәр, шаян бала-чага кызыл ләпек чәпәп чыккан шикелле буйдан-буйга шадраланып тора.* В.Имамов

**Юнып җибәрү** Бераз, берникадәр юну. *Кайры үзе дә көймә кебек озынча иде. Бары тик башын гына юнып җибәрергә кирәк.* З.Хөснияр

**Юнып йөрү** Һаман, гел юну. *Почмак саен рәсем ясап, агач юнып йөргәнче, институт бетер диюемнең файдасын күрәсең бит хәзер.* Г.Каюмов

**Юнып карау** Юнырга тырышу; сынау өчен юну. *Трубаларны кисеп карадылар, тишеп карадылар, юнып карадылар. Берсенә дә бирешми торган булып чыкты пыялаланган торба.* Казан утлары

**Юнып кую** Алдан юну. *Моңарга [егеткә] шоп-шома итеп ике агач юнып куйганнар.* Әкият

**Юнып тору** Даими юну; һаман, һәрвакыт юну; хәзерге вакытта юну. *Кәлимулла абзый миңа бүрәнәләрнең кайрысын, ботак-чатагын юнып торырга гына кушса да, остага карап мин дә бурарга өйрәндем һәм икеме, әллә өчме көн эчендә мунчаны өлгертеп тә куйдык.* Әлмәт таңнары

**Юнып утыру** *сөйл. к.* **юнып тору**. *Барый пәке белән кармак сабы юнып утыра иде, эшеннән аерылмый гына, дустына җавап кайтарды.* А.Гыймадиев

**Юнып чыгу** Башыннан ахырына кадәр, һәрберсен бер-бер артлы юну. *Аңа капкач тирәләрен балта белән юнып чыгарга кушыла.* Кызыл таң

**Юнып яту** *сөйл. к.* **юнып тору**. *Беркөнне Хәлим үз-үзенә аптырады: кулындагы агач кисентесеннән нindидер кыз сынын юнып ята ласа ул!* Г.Гыйльманов

**ЮНЫШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **юну**. *Ул [Бәхтияр] картка кәрзин үрешә, чыбык юныша.* Казан утлары

2) Юнып, һәртөрле нәрсәләр яки детальләр ясау; даими рәвештә нәрсәдер юну. *Әйтик, Илһамның кызып-кызып юнышкан, нәрсәдер ясаган чагы, ә Айнур шахмат уйнарга тели.* Ф.Садриев. *Агач юнышу белән өчәр-дүртәр бүрәнәдән бура өлешләре пазлары алынып, бик җайлы гына итеп оештырылып, хәреф-саннар сугылып куелган иде.* Р.Гаязетдин

**Юныша башлау** Юнышырга тотыну

**Юнышып тору** Әле, хәзерге вакытта юнышу; даими, гел юнышу

**Юнышып утыру** *сөйл. к.* **юнышып тору**. *Һади, әнисе алдында гаебен сизенеп, тын гына юнышып утыра.* А.Гыйләҗев

**ЮНЬ** I *и.* **1.** 1) *сир.* Карау яки бару юнәлеше, тараф. *Ул киткән юньгә озак карап торды*

2) *күч.* Эш яки үз-үзеңне тоту рәвеше. *Мин бит усал әйтмәдем, бары үзләре шаярганга гына ул юньгә киттем.* Ш.Камал

3) *күч.* Тиешле тәртип; тәртиплелек, инсаф, рәт. *Иле юкның җире юк, тормышының юне юк.* Мәкаль. *Моңа кадәр яшәвен юньгә салырга тырышып та, яшьлеге белән дә артык сизмәгәндер.* М.Кәбиров. *Әгәр дә илдә юнь, адәмдә им булса, шушы шигырь җимешләреннән милләтне сыйлы-хөрмәтле итәр иделәр.* Ф.Яхин

4) *күч.* Хәл, рәт; мөмкинлек, чара. *Җан биргәнгә юнь биргән.* Мәкаль. *Юнең, көнең үзең белән.* Мәкаль. *Бик үтә ачлык елларның берсендә, авылда хәер сорашып та тамак туйдырырга юнь калмагач, ул бер кешегә утырган да, Ходай юнь бирер әле дип, калага киткән.* Г.Ибраһимов

5) *күч.* Файда, игелек. *Икенче агаем Белорет ягында завод тирәсендә буталып йөри иде. Юнь чыгара алмагач, соңрак кире әйләнеп кайтты.* М.Кәрим. *Ул колга башына мендең ни дә, менмәдең ни, аңардан менүчегә ни файда да, карап торучыга ни юнь?* Д.Булатова

6) *күч.* Көч, сәләт. *Мәрхүм бай, моның картлыгына карап, җиңел эшләргә генә куша, берәр авыр эш тапшыра башласа: – Әй син, яшьтәш, кая, менә бу эшкә юнең җитәме, булмаса, башка берәрсен кушармын!.. – дип сүз башлый икән.* Г.Ибраһимов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Бар яктан да тәртиптә булган, бернинди кимчелексез, бер дигән. *Үзем тыныч, гаҗәп тыныч, һични уйламыйм, әгәр йөрәкнең әкрен генә савып торуын сизмәсәм, бөтенләй юнь кеше мин.* Ә.Еники

2) Уңай, әйбәт, яхшы. *Юнь хәбәр җәяүләп, ә юньсезе очып килә, дигәндәй, Саматның язмышын бюро хәл итәчәк, дигән хәбәр бөтен авылга таралды.* Казан утлары

3) Уңайлы, җайлы, ипле. *Моны сөйләргә шушыннан да юнь вакыт тапмадыңмы*

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) *күч.* Уңайлы, җайлы, ипле булып. *Елы да бик юнь килде шул. Елы килгәч, кортлар да балны нык ташыдылар.* А.Хәсәнов

2) *күч.* Вакытын туры китереп. *Назыйфның комбайны ватылуы бик юнь килде.* В.Гали

◊ **Юньгә дигән** Кеше арасына чыкканда кия торган, кешелеккә кия торган, рәешкә кия торган. *Түрдәрәк, яңа үтүкләнгән бер өем күлмәк-майкалар артында Хәмдия, тырышып-тырмашып, иренең юньгә дигән бердәнбер костюмын юеш щётка белән ышкып азаплана.* И.Хәйруллин. **Юньгә керү** 1) Акыллылану, тәртипләләнү. *Кычыткан белән дә пешекләп карадылар, каеш чыбыркы да «ашаттылар», әмма юньгә кермәде, җитмәсә тәртә ватып чапкынлаучы айгыр кебек кызу канлы иде.* Ф.Яхин. *Тау урыныннан күчсә күчәр, юньсез юньгә кермәс, дип нәкъ менә шундыйлар турында әйтәләр дә инде.* Кызыл таң; 2) Рәтләнү, кәеф күтәрелү; савыгу, сәламәтләнү. *Яңа җиргә күчкәч, хәсрәтем онытылмасмы, юньгә кереп булмасмы, дип уйлады ул.* Ә.Еники; 3) Яхшыру, әйбәт якка үзгәрү, җайга салыну. *Соңгы елларда гына бераз юньгә керә башладык.* Татар әдипләре. **Юньгә килү к. юньгә керү**. *Җиде кат тиресе салынырлык итеп камчыласаң, иң чыгымчы ат та юньгә килә.* В.Имамов. **Юньгә китерү** Тәртипкә салу, яхшыга үзгәртү, рәтләү. *Әмма хатын-кыздан башка гына илйортыбызны юньгә китереп булмас шикелле.* Казан утлары

**ЮНЬ** II *с.* **1.** Арзан, очсыз. *– Хәзер остасы да очсыз була, мүге дә юнь була, – дия иде.* Г.Исхакый

**2.** *рәв. мәгъ.* Арзанга, очсызга. *Бик юнь сатма*

**ЮНЬ ИТҮ** *ф.* 1) Юнәтү, бар итү, булдыру. *Өс-башын юнь итү*

2) Уңай дип санау; куәтләү, хуплау, җилкендерү. *[Иблис] Әйтәемме? Кайсыгызның дәрте бар? – Әйт тә әйт, –*

*дип юнь итә шунда халык, Барсының да дәртләре ялкынланып...* Ш.Бабич

**ЮНЬ КЫЛУ** *ф. к.* **юнь итү**. *Торабара Фазыл аңа кадәр эшләгән бик күп агайлар ише, калын тиреле зимагурга әверелеп, Ходай ни юнь кылса – шуны ашап, кемне сөйсә – шуңа юанып, получкадан получкага чаклы вакыт үткәрер өчен генә, гамьсез яшәргә өйрәнер, күнегер, иялəшер.* Казан утлары

**ЮНЬЛӘНҮ** I *ф.* Юньле булып китү; рәткә керү, акыллылану. *Шәйхи бераз юньләнгән кебек күренгән иде, ләкин озакка бармады.* Г.Ибраһимов

**ЮНЬЛӘНҮ** II *ф. сөйл.* Арзанлану, очсызлану. *Күз күне яшелчәләр юньләнү*

**ЮНЬЛӘП** *рәв.* 1) Игътибар белән, анык, төгәл итеп, ахырга кадәр. *Аның сүзләрен Илһам юньләп тыңламады.* Казан утлары

2) Тиешенчә, рәтләп, чынлап торып. *Аның хәзер юньләп ял итәрлек тә вакыты юк. Ул муеннан эшкә баткан.* Казан утлары. *Ләкин аның ачы тавышы, коега төшкән таш кисәгедәй, гөж-ж итеп улап торган вокзал эчендә юньләп ишетелмичә дә калды.* Казан утлары

**ЮНЬЛЕ** *с.* **1.** 1) Инсафлы, әйбәт, яхшы холыклы; мәрхәмәтле, рәхимле. *Үги атасы да бик юньле кеше, үз кызы кебек күрә.* А.Әхмәтгалиева. *Әй улым, улым, бабаң үз гомерендә кешенең энәсенә дә кагылмады, әтиең дә бик юньле кеше.* А.Хәйретдинова

2) Әйбәт, яхшы сыйфатлы, затлы. *Балта остасының юньле балтасы булмас, чабата ясаучының юньле чабатасы булмас.* Мәкаль. *Башта бер тиенгә алып ашап карыйм, әйеме, аннан инде, юньле нәрсә булса, тагын алырмын.* А.Фәләх

3) Тиешенчә булган, җитәрлек күләмдәге. *Юньле печәне дә булмагач, күптәнге юллар да сакланмаган, сукмак та юк хәтта.* А.Тимергалин

4) Мәгънәле, нәтиҗәле; әйбәт тәэсир калдыра торган, күңелгә ятышлы. *Ләкин зиһене таркау, юньле бер генә фикер дә башына килми иде.* А.Вергазов. *Ә Ләйсән белән безнең тырт та пырт. Телдә бер юньле сүз, матур җөмлә юк. Гел үпкәләш тә кычкырыш...* А.Гыймадиев

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Тәртипле, тәрбияле, тыныч, тиешле кагыйдәләрне бозмыйча. *Соңга калсам, юньле утырыгыз... Ярамаган эшләрегез булмасын.* К.Тинчурин

2) Тиешенчә, таләп ителгәнчә, яхшы, әйбәт итеп. *Әгәр син монда юньле эшлисең килсә, безнең сәвит егетләре белән бер аяктан йөре, дидем.* Г.Ибраһимов

**3.** *и. мәгъ.* Булдыклы, уңган кеше; акыллы, тәрбияле, тәртипле кеше. *Юньлегә юнь чыга, юньсезгә йон чыга.* Мәкаль

◊ **Юньле чакта (чагында)** 1) Ул-бу булганчы. *Сазлыкка кереп батканчы, юньле чакта «бизнестан» китәргә уйласа да, көн саен килеп торган акчага түзеп каршы килә алмаган эшмәкәр.* Ватаным Татарстан; 2) Берәр начар нәрсә эшләгәнче, усаллыкка киткәнче. *Син нәрсә, аңламыйсыңмы әллә? Юньле чакта күз алдыннан олак!* Г.Гыйльманов

**ЮНЬЛЕ́-БАШЛЫ** *с.* **1.** 1) *к.* **юньле**. *Аннан да ерак авыл юктыр. Юньле-башлы юл да юк.* Г.Гыйльманов

2) Рәтле, мәгънәле, эчтәлекле. *Шул көннәрдә янына килеп чыккан Рәдиф дусты да юньле-башлы киңәш бирә алмады.* Г.Гыйльманов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Нәтиҗәле рәвештә, файдалы итеп. *Әгәр ул гаскәрен бернигә нөгәргә бүлмәсә, тауларындагы тарлавыкларга кергәч, юньле-башлы селкенә алмаячак.* В.Имамов

2) Тиешенчә, тиешле дәрәҗәдә. *Иртәдән дә юньле-башлы сөйләшмәде, тырт та пырт, койрыгын чәнчеп чыгып югалды.* А.Гыйләҗев

**ЮНЬЛЕЛӘНҮ** *ф.* Юньлегә әйләнү, рәтләнү, әйбәтләнү. *Сабирага, инде юньлеләнгән тормышына сөенеп, Ходайга дога кылырга кирәк булгандыр.* Р.Рахман

**Юньлеләнә бару** Торган саен юньлеләнү

**Юньлеләнеп китү** Күзгә күренерлек дәрәҗәдә юньлеләнү

**ЮНЬСЕЗ** *с.* **1.** 1) Булдыксыз, эшлексез; тәртипсез, тәрбиясез, тискәре йогынты ясый торган. *Ә урамда юньсез дуслар тиз табыла икән...* Г.Гыйльманов

2) Уйламыйча эш итүчән, акылсыз. *– Бар бит юньсез бәндәләр! – дип телен шартлатты ул, тапталган игенне күрсәтеп.* А.Гыйләҗев

3) Тискәре сыйфатлардан, үзлекләрдән торган, начар. *Юньсез үрнәк тиз йогышлы була, дигәннәре хак икән шул.* В.Имамов

4) Тупас, дорфа, ятышсыз. *Каян килә алайса синең телеңә бу юньсез сүзләр?* Г.Гыйльманов

5) Мәгънәсез, чуалчык, буталчык. *Мәгънәсез, юньсез уйлар кереп Бутамаса иде күңелне.* В.Галиев

**2.** *и. мәгъ.* 1) Булдыксыз, уңмаган кеше. *Уңган эшен бетерер, юньсезне эше бетерер.* Мәкаль

2) Акылсыз, тәрбиясез, тәртипсез адәм. *Син юньсез аркасында хәзер халыктан сүз ишет инде.* Г.Әпсәләмов

3) Явыз, әшәке кеше. *Кайчандыр укып исендә калдырган Германия канцлеры Бисмарк сүзләре хәтерендә яңарды: «Революцияне зур акыл ияләре әзерли, фанатиклар ясый, ә җимешеннән әшәке кешеләр, юньсезләр файдалана».* Р.Кәрами

**ЮНЬСЕЗЛӘНҮ** *ф.* 1) Юньсез булып китү, юньсезгә әверелү. *Менә бераз гына әзерләнсен Харис, --- мәктәпкә баргач юньсезләнеп утырмас, мин беләм дип кул күтәреп кенә торыр.* З.Мурсиев

2) Юньсезлек күрсәтү, юньсезлек эшләү. *Тик башкалар гына юньсезләнеп арага кермәсеннәр дә юк-бар белән башкаен әйләндермәсеннәр!* Ф.Яхин

**Юньсезләнә бару** Торган саен ныграк юньсезләнү. *Тормыш йөгән хатын-кызлар тарта, ә ир-егетләр көчсезләнә, юньсезләнә бара.* Кызыл таң

**Юньсезләнә башлау** Юньсезләнергә тотыну

**Юньсезләнә төшү** Тагын да юньсезләнү

**Юньсезләнеп алу** Бераз, берара вакыт юньсезләнү

**Юньсезләнеп бару** Аз-азлап, акрынлап юньсезләнү. *Ни хәл итмәк кирәк, җәмгыятебез юньсезләнеп барган бу илдә борчыган мәсьәләләр бик күп шул.* Мәйдан

**Юньсезләнеп йөрү** Һаман, гел юньсезләнү. *Үземнең дә ник берсенең юньсезләнеп йөргәнен күргәнем булсын.* Н.Гариф

**Юньсезләнеп тору** Гел юньсезләнү; әле, хәзерге вакытта юньсезләнү. *Борынгы мәчет таштан булган икән, бүген ник юньсезләнеп торырга, булгач шәбе булсын, горур басып торсын.* З.Мурсиев

**ЮНЬСЕЗЛЕК** *и.* 1) Юньсез булу сыйфаты. *– Дөньясында юньсезлек җитәрлек, улыңны да тәрбиясезлектән сакла, – дип, киңәшләрен биреп, [ул] кат-кат сөйләнде.* Н.Гариф

2) Ярамаган эш, начарлык. *Мин, бәлки, эчледер, көнчедер, булдыра алганча усалланам, юньсезлек тә эшлим.* Р.Сибат

**ЮНЬЧЕЛ** *с. сөйл.* Рәтләргә, булдырырга тырыша торган, хуҗалыкчыл, хәстәрле, кайгыртучан. *Ил терәге – яучыл ир белән юньчел хатын.* Мәкаль

**ЮРА** *и.* Җирнең геологик тарихында мезозой эрасының урта бер геологик чоры. *Мезозой эрасы өч чордан: триас, юра һәм акбур чорларыннан торган.* Биология

**ЮРАЛЫШ** *и.* Аңлану, аңлашылу күренеше, сыйфаты яки хәле. *Мәкальнең хикмәте аңлашылса да, аның актив мәгънәсе һәм роле тормышта кулланган вакытта ачыла, аннары аны кем һәм нинди максат белән әйтүенә карап мәгънәсе авыша, төрлечә юралыш таба.* Н.Исәнбәт. *Әмма Галимә ахирәте әйткән юралыш аның күңеленә кереп кала.* Ә.Гаффар

**ЮРАМАЛ** *рәв. диал. к.* **юрамалый**. *Мин аны юрамал гына әйттем, сине сынар өчен генә.* С.Поварисов. *Фазылханов эндәшми торды, ул юрамал вакытны суза, икеләнгән булып кылана.* З.Мурсиев

**ЮРАМАЛЫЙ** *рәв. сөйл.* 1) Чынлап түгел, шаярып, кызык өчен, көлке итеп. – *Чынлап түгел ич ул! Әкият кенә бит!* – *диделәр.* – *Көлдерер өчен юрамалый гына сөйләде бит, мәзәк итеп!* Г.Бәширов

2) Сынап карар өчен генә. *Ул көнне футболка, яшел итәк һәм тапочка киеп чыктым, юрамалый гына, ни әйтер икән дип...* Р.Кәрами. – *Отлично, акыллым, отлично, димәк, мин кеше буласыгызны алдан күргәнмен,* – *диде ул, егетне юрамалый сөендереп.* Р.Рахман

3) *к.* **юри**. *Беләм инде, бу вакытта кәнизәкләр юк: ләкин юрамалый, оятлы итәр өчен сорыйм аны.* Ф.Әмирхан

**ЮРАТУ** *ф.* Ырымчыдан, фалчыдан үзеңнең киләчәгеңне, язмышыңны әйттерү. *Урыс улап, татар юрап китерер дигән кебек, төш юратып без дөрес эшлибезме?* Шәһри Казан

**Юратып алу** Тиз генә юрату. *Ул бәхетне мин моңарчы күрмәгән кара алмаларыннан сорап, юратып аласым килә.* Р.Рахман

**Юратып карау** Тикшерү, сынау өчен юрату. *Карале, ул төшеңне абыйның үзенә сөйләп, аңардан юратып карарга кирәкмәс микән?* Казан утлары

**ЮРА́У** *ф.* 1) Фараз итү, аерым күренешләргә, билгеләргә бәйләп, киләчәкне әйтү. *Атасы Йагъкуб аның төшен яхшыга юрап, Раббың сине Исхак белән Ибраһим кебек пәйгамбәр итеп сайлыйдыр вә сиңа төш юрауны өйрәтәдер дип аңлата.* А.Тимергалин

2) Теләк теләү; берәр эш, ният уңышлы чыксын дип, билгеле бер ырым үтәү. *Борынгырак заманнарда авыл халкы, игеннәр ишелеп уңсын, бөртекләре авыр, салмак булсынга юрап, орлык белән бергә йомырка да чәчә торган булганнар!* Г.Бәширов. *Ах, алмагач, ак алмагач миңа Бәхет юрап ак шәл ябынган.* Г.Гыйльманов

3) Билгеле бер күренешнең, эшхәлнең килеп чыгуын берәр сәбәп белән аңлату, шуннан дип уйлау. *Мәгариф бүлегендәгеләр аннан соң да тынмады, әле тегеләй, әле болай юрап, Мортазинның җанын ашадылар.* В.Имамов. *Ул Сәхиләнең дәртлелеген дә, көлүен дә аның яшьлегеннән, үзе белән бик бәхетле яшәвеннән дип юрады.* Д.Каюмова

**Юрап бару** Һәрберсен, булган берсен юрау. *Әнә җизни бөтенесен яхшыга юрап бара: сугышта солдатларның әфисәрләрен тыңламый башлауларын да, кибеттә әйбер бетүен дә.* Г.Бәширов

**Юрап бетерү** Әлләниләр юрау. *Күңел бит ул әллә кайларга йөгерә – [Романның] каймак урлап ашаган песи сыман тавыш-тынсыз гына, шома гына йөреп ятуын [Галия] әллә нәрсәләргә юрап бетергән иде.* Д.Булатова

**Юрап карау** Юрарга тырышу, юрап сынау. *Кыз-кыркын --- яңа ел кичәләре оештырган, кичәләрдә тамашалы уеннар уйнаганнар һәм «Кулымдагы йөземнең исемнәре...» дип башланган җырлар ярдәмендә яңа елда ниләр булачагын юрап караганнар.* А.Тимергалин

**Юрап килү** Элек-электән үк, күптәннән бирле юрау. *Ләкин бүгенгә кадәр ул моны гел яхшыга гына юрап килде.* Г.Әпсәләмов

**Юрап кую** Алдан юрау. *Әмма иртән Фәхрәзи бу төшне һич шикләнүсез болай юрап куйды: ниндидер куркыныч яный.* З.Мурсиев

**ЮРГА** *и.* **1.** Юргалап чаба торган ат; *русчасы:* **иноходец**. *Атның солтаны – юрга.* Мәкаль. *Бу кола айгыр бөтен тирә-якның сабантуйларында беренчелек урынын тоткан юрга ак байталның баласы иде.* Г.Рәхим. *Бәхтиярның куллары дилбегәне аз гына күтәрә төшүгә, кара юрга ачык капкадан чабып чыгып та китте.* Н.Яһудин

**2.** *с. мәгъ.* Юргалап чаба торган. *Күңелемнең юрга тайдай уйнап чапкан чаклары!..* А.Гыйләҗев

**ЮРГАЛА́У** *ф.* 1) Берьюлы ике уң аягын һәм ике сул аягын алмашлап алга ташлап чабу (ат тур.). *Ат юргалар, иясе дан алыр.* Мәкаль. *Инде ул юрганың сылулыгы, кызлар шикелле буен-сынын биетеп, вак-вак кына атлап юргалап китүләре!* Г.Бәширов

2) *күч.* Вак-вак адымнар ясап, йөгергән сыман җитез атлау. *Әнә ул [сабый чак көяшы] Кама ягындагы уйсулыктан кып-кызыл булып, көлемсерәп килеп чыга да чиләкләрен мөлдерәмә тутырып чишмә суы күтәргән матур һәм оялчан кыз шикелле, сөйкемле генә юргалап, авыл каршындагы үргә менеп бара.* Казан утлары

**ЮРГАН** *и.* 1) Ябыну өчен мамык, йон һ.б.ш.ны ике тукыма арасына кыстырып, сырып тегелгән урын-җир әйбере. *Җәен әйрәнсез булма, кышын юргансыз булма.* Мәкаль. *Нигәдер, хатын-кыз кулы тисә, мендәрләр кабарып тора, юрганы да пөхтә җәелә, серен беләләр алар.* К.Кара

2) *күч.* Нәрсәне дә булса каплап алган тышкы катлам, каплам. *Кырга ак кардан Юрган ябылган; Җир язга чаклы Уйкуга талган.* Г.Тукай

◊ **Юрган асты фикерләре** *мыск.* Үзен бик хикмәтле кеше санап, әллә нинди каһарманлыклар кыла алуына ышану; шундый фикер һәм фаразлар. *Боларның укый торган китаплары Али батыр (хәзрәти Гали), Камыр батыр, Чилбәр батырның җиде башлы диюләр белән сугышкан, Әбүгалисина хәлен тасвир иткән ялган кыйссалардан узмаганга, бөтен зиһенләре вә миләре юк хыял вә юрган асты фикерләре белән чуалып беткән буладыр.* Безнең мирас.

**Юрган кыска** Мөмкинлек җитәрлек дәрәҗәдә түгел. *Атларга мөмкин булган хөрмәтне күрсәтергә тырышалар, ләкин юрганың кыска булгач, аякны капласаң – баш ачыла, башны капласаң – аяк шәрә кала.* Н.Әхмәдиев.

**Юрганыңа карап аяк сузу** Мөмкинлегеңә, хәлеңә карап эш итү. *Юрганыңа карап аягыңны сузасың дигәндәй, Салих машинаның тотылганын – арзанрагын алуны хуп күрде.* Татарстан яшьләре

**ЮРИ** *рәв.* 1) Чынлыкны яшереп, хәйләләп; сынап. *Колын, аны [Хәерлебәнатны] үртәп уйнаклый-уйнаклый, арба янына ук килә дә юри артта кала.* А.Гыйләҗев. *Вахит малайны юри сөйләштерә иде.* Г.Гыйльманов. *Сания машинадан тиз генә төшми. Берәрсе*

*күрсен дип, юри озак кыймылдый.* А.Гыймадиев

2) Шаяртып, кызык өчен, көлке итеп, юрамалый. *Мин аны башта шаяра, юри мине куркытырга гына маташа дип торган идем.* Г.Рәхим. *Моны Рәфис үзенең бу хыялый маҗараларын юри, аннан уздыру өчен уйлап чыгарадыр.* А.Вергазов

3) Махсус рәвештә, белә торып; үч итеп, кире ният белән, усаллык белән. *Рәмзи әллә онытты, әллә исендә булып та берәр төрле мәкер белән юри онытканга салышты – Равилгә кайсы вариантны алырга икәнен әйтмәде.* В.Нуруллин. *Әллә инде капкабызны җил ачкан, әллә берәрсе юри ачып киткән, төннәрнең берендә Матурыбыз, ишегалдыннан чыгып китеп, болындагы атлар көтүенә барып кушылган.* А.Хәсәнов

**ЮРИ́ДИК** *с.* 1) Юристка, юристларга караган. *Киләчәктә юридик эшчәнлек белән артист тормышын аралаштырып булырына ышанам.* Кызыл таң. *Юридик стаж*

2) Юристлар, юстиция хезмәткәрләре эзерләү белән бәйле. *Күптөрле эшкә чумса да, Мидхәт, белеменең әллә ни мулдан түгеллеген абайлап, уку ягын кайгырта башлый һәм Казанга, кичке юридик курсларга бара.* Т.Әйди

3) Хокук кануннарына, нормаларына, аларны гамәлдә куллануга һәм гадел хөкем чыгару кагыйдәләренә бәйләнешле; хокукый. *Безнең эрага чаклы ук әле Греция, Кытай һәм башка ил галимнәренең юридик кануннар хакында әйткән шактый эчтәлекле, мәгънәле, уйландыргыч, кыйммәтле фикерләре бар.* С.Поварисов

4) Канунга туры килгән; рәсми, формаль. *Сүз монда мәсьәләнең юридик ягын хәл итү турында гына барды бугай.* А.Хәсәнов

**ЮРИ́-МАРЫЙ** *рәв.* Чынлап түгел, юри генә. *Яңа көй иде бу Исхак өчен, хәтта атаклы гармунчы шадра Васил өчен дә яңа иде,ахры, ул, башка кызлар җырлаганда, бакаларын юри-марый шырылдата-шырылдата кушылып китә торган иде.* А.Гыйләҗев

**ЮРИ́-МЫРЫЙ** *рәв. к.* **юри-марый**. *Юри-мырый әйткәнне тыңламый, ялганны сизә иде карчык.* М.Маликова

**ЮРИСДИ́КЦИЯ** *и. лат.* Дәүләт органының закон яки башка хокукый актта беркетелгән вәкаләтләре, хокук чикләре. *Элегрәк судья нигездә иратлар һөнәре дип саналса да, бүген инде гомуми юрисдикция судларында хатын-кызлар күбрәк тә әле.* Татарстан яшьләре

**ЮРИСКО́НСУЛЬТ** *и. лат.* Учреждение, оешма һ.б.ш.ның мәнфәгатьләрен яклаучы махсус юрист. *Менә шунда ул кечерәк кенә бер консерв заводында юрисконсульт булып эшли башлый.* Р.Мирхәйдәров

**ЮРИСПРУДЕ́НЦИЯ** *и. лат.* Хокук фәннәре, хокук гыйлеме. *С. Максуди үзенең теоретик әзерлеге, хокук белеме, юриспруденция өлкәсендәге тирән карашлары, сәясәтчелек таланты, ораторлык осталыгы, гомумән, интеллектуаль дәрәҗәсе белән --- аерылып тора.* М.Хәсәнов

**ЮРИСТ** *и. нем.* Юридик белеме булган кеше, хокук белгече, юстиция хезмәткәре. *Нәкъ шул Думадагы депутатлык эшчәнлеге белән ул [С. Максуди] күренекле хокук галиме – юрист, мәшһүр оратор булып китә.* М.Хәсәнов

**ЮРТАК** *и.* **1.** 1) Юыртып – алгы уң аягы белән арткы сул аягын берьюлы һәм алгы сул аягы белән арткы уң аягын берьюлы алмашлап алга ташлап чаба торган, башка чабу рәвешенә күчмичә, озак юыртып бара ала торган ат; *русчасы:* **рысак**. *Мотор [кушаматлы бия] ипподромнарда тәрбияләп үстергән метис түгел, туган як болыннары тудырган, шунда үскән чын юртак иде.* А.Хәсәнов. *Күренеп тора нәселле ат, яхшы юртак.* В.Ильясов

2) *сөйл.* Чабышкы. *Юртактан тир кипмәс, юбалгыдан чир китмәс.* Мәкаль. *Юртаклар старт буласы урынга туплануга, әллә кайда тонык кына кыңгырау шалтырады.* В.Имамов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Юыртып чаба торган; йөргәндә башлыча юыртып йөри торган. *Тормыш аны, баш бирми торган юртак ат кебек, көтүче малайга аңлашылмаган үз юлыннан үзе теләгәнчә алып бара бирде.* Г.Әпсәләмов. *Әткәй иртә таңнан «Җүләр» исемле үзен үзе белештерми чаба торган юртак айгырны җигеп эшкә китә, кич арыпталып өйгә кайта.* Р.Вәлиев

2) *күч.* Тиз, кызу йөгерә торган. *Куркакның күңеле юртак (андый-мондый хәл булса качам диеп кенә тора).* Н.Исәнбәт. *Сәетнең эченә билгесез юртак шом үтте.* Т.Галиуллин

**ЮРТАКЛА́У** *ф. к.* **юырту**. *Спортның бу төрендә дә үзенчәлекләр бар, мәсәлән, уртадагы ат бөтен дистанцияне юртаклап, ә ян-яктагы атлар бары тик сикертеп кенә чабарга тиеш.* Шәһри Казан

**ЮРТАКЛЫК** *и.* Юыртып чабу сыйфаты; тиз юырту, башка чабу рәвешенә күчмичә юырта белү сәләте. *Айгырдан да уңдылар алар, гәүдәгә ул тиклем булмаса да, киң күкрәкле, нык аяклы, озын, мул яллы кызыл айгыр юртаклыкта үз ишләренә һич ал бирми торган иде.* А.Гыйләҗев

**ЮРТУ** *ф. к.* **юырту**. *Юл буе юртып тирләгән атның өстен бәс каплаган иде.* В.Имамов. *[Сөмбелә] Бер сүз әйтми атларның берсенә атланды, икенчесенең тезгененнән алды һәм җилле генә юртып кузгалып китте.* М.Хәбибуллин

**ЮРТЫШ** *с.* Сукбай. *Әһә, миннән кызымны эзләтеп, үзең аны монда юртыш Хамматка биреп ятасыңмы?* Н.Исәнбәт

**ЮСТИ́ЦИЯ** *җый. и. лат.* Хокук һәм хөкем чыгару эшләре, суд учреждениеләре системасы. *Болар [машинкада басылган текст] прокурор Азлархановның илдәге хокук, дәүләт төзелеше, юстиция, суд алып бару эше, прокуратура, законнар турында фәнни уйланулары булып чыкты.* Р.Мирхәйдәров

**ЮСЫК** *и.* **1.** 1) *бор.* Үз-үзеңне тоту кагыйдәләре, этик күрсәтмәләр. *Ал юсык* (аксөякләр өчен кагыйдәләр). *Кара юсык* (гади халык өчен кагыйдәләр). *Юсыкның шулай ук тәртипле, әдәпле дигән мәгънәсе дә бар икән, ягъни юсыкка буйсынган кеше тәртипле һәм әдәпле булып аңлашыла.* Н.Фәттах

2) Канун, устав

3) Церемониал, тантана тәртибе. *Хан күтәрү юсыгы*

**2.** *с. мәгъ. диал.* Тәртипле, әдәпле. *Юсык кеше аякка карамас, күзгә карар.* Мәкаль

**ЮСЫККА** *рәв. бор.* Билгеле бер йоланы, кагыйдәне үтәү йөзеннән. *Ал юсыкка* (рәсми кагыйдә, боерык белән). *Кирәкмәгән юсыкка* (билгеле бер йоланы үтәү өчен генә). *Ясамаган юсыкка кысылма.* Мәкаль (ясау – «әмер, боерык бирү» мәгъ.)

**ЮСЫКЛАП** *рәв. диал.* Әйбәтләп, иплэп, яхшы итеп. *Юсыклап сөйләшеп кара*

**ЮСЫ́К-ЮРЫК** *җый. и. бор.* Һәртөрле рәсми кагыйдәләр. *[Ул] Иң калку җиргә биек таш утыртып куйган, ташны уеп, киләчәк буыннар өчен үзенең изге сүзләрен – юсык-юрык кагыйдәләрен язып калдырган.* Н.Фәттах

**ЮСЫН** *и. диал. к.* **юсык 1.** *Юлчыга сусын бирү – юсын.* Мәкаль. *Сугышчылар арасындагы мөнәсәбәт юсын – хәрби устав һәм яркә-сурәт – гомуми хокук буенча тәкъдир ителгән.* Р.Әхмәтьянов

**ЮТӘЛ** *и.* Йөткерү күренеше, йөткереп авыру. *Ютәл йөткерекне баса.* Мәкаль. *Каһәр суккан ютәл торган саен ныграк буды аны.* В.Имамов

**ЮТӘЛЛӘТҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **ютәлләү**. *Сигаретның ачы исе ютәлләтә.* Р.Мөхәммәтшин

2) *з.-сыз* Ютәл тоту, йөткертү. *Ашыйсы килми, төннәрен тирләтә һәм күкрәкне авырттырып ютәлләтә.* Шәһри Казан

**Ютәлләтә башлау** Ютәлләтергә тотыну. *Шул чакта [тузанда] ютәлләтә башлый.* М.Гафури

**ЮТӘЛЛӘ́Ү** *ф.* Туктаусыз йөткерү; ютәл белән авыру. *[Әтисе] Ютәлләп уяна да, мич алдына чүгәләп, шул тәмәкесен гөжләтеп утыра.* З.Мурсиев

**Ютәлләп алу** Аз гына, кыска вакытлы ютәлләү. *Кинәт Фәһимә [җырлаганда] төртелеп калды, ютәлләп алды һәм алдагы ике юлны тирән күкрәк тавышы белән дәвам итте.* Д.Каюмова

**Ютәлләп җибәрү** Кинәт ютәлли башлау. *Сәламәтлеген тикшергән чакта, Галимҗан тагын да нык ютәлләп җибәргән.* С.Поварисов

**Ютәлләп кую** Кинәт, бер тапкыр ютәлләү. *Ара-тирә буылып ютәлләп куюы гына бу малайның тәнендә яшәү гаме барлыгы хакында әйтеп тора.* Г.Гыйльманов

**Ютәлләп тору** Гел, һәрвакыт ютәлләү; берара ютәлләү; әле, сөйләү моментында ютәлләү. *Читкә борылып, беркавым ютәлләп торды.* М.Хәсәнов. *Юк болай, карчык кына ютәлләп тора, – дип мыгырданган [Йосыф абзый].* Р.Зәйдулла

**Ютәлләп чыгу** Билгеле бер вакыт арасының башыннан ахырына кадәр ютәлләү. *Ул төне буе корык-корык ютәлләп чыга, йоклый алмый.* Р.Батулла

**Ютәлли башлау** Ютәлләргә тотыну. *Ул, ютәлли башлап, тиз генә кесәсеннән кулъяулык чыгарып, авызын томалады.* М.Хәсәнов

**ЮТӘ́Л СЫРХАВЫ** *и.* Үпкә чире, туберкулёз

**ЮТӘ́Л ХАСТАСЫ** *и. к.* **ютәл сырхавы**. *Ата малы түкәнде, исән калган аяклы малларын мур кырды, дуслар-мәҗлестәшләр таралды, картая башлагач, үлем шаукымы кагылгач, Комратка бетмәс ютәл хастасы ябышкан, дип сөйләделәр.* Р.Батулла

**ЮУ** *ф.* 1) Сабын, порошок һ.б. ярдәмендә әйберне суда ышкып пычрактан арындыру. *Кара ташны юсаң да агармый.* Мәкаль. *Җиз чиләкләрне көлләп юып көянтәләп суга барулар дисеңме?!* А.Хәйретдинова

2) Берәр төрле өслекне чылатып, шуның буенча агып үтү. *Маңгаеннан аккан кайнар тире Юып төшә ике яңагын.* М.Җәлил

3) Үзе белән агызу, эләктереп алып китү. *Иртә язларын ук җилләр аның [төпнең] өстендәге карны җәһәт кенә ялмап ала, җылы яңгырлар тузан, чүп кисәкләрен өстеннән юып төшерә, кояшның нурлары тиз генә киптереп тә куя икән.* Р.Фәйзуллин. *Әллә кайлардагы тау итәкләрен юып килгән инеш суының болганчыклыгына да, йөгереп керүгә үк тәннәрне куырып алган салкынлыгына да, аякларын көзән җыера башлавына да игътибар итмәде ул.* А.Фәләх

4) Берәр өслектәге эз, язу һ.б.ш.ны шомартып бетерү, юкка чыгару, тигезләү. *Танулары авыр ташлардагы Тамгаларны җил һәм яңгыр югач.* Ә.Рәшит. *Дулкын юган йөргән эзләрне.* Сөембикә

5) *күч.* Һич тә булмаган кебек юк итү, әсәрен дә калдырмыйча бетерү. *Күзендәге якты нурны шомлы уй юып төшерде.* Г.Гыйльманов. *Кайтса, керсә – үзенеке, Рәмзиясенең ачык йөзе аруталуларын юып төшерә.* Н.Хәсәнов

6) *күч.* Берәр яхшы эш, мөгамәлә яки үкенү, газаплану һ.б.ш. юллар белән гаепне, гөнаһны кичертү. *– Бу хурлыкны каныбыз белән генә юа алабыз! – дип ярсыды [Верещагин].* Г.Әпсәләмов. *Намуслы хезмәтем белән ата-анам өстенә ягылган гөнаһны юарга телим.* А.Гыйләҗев

7) *күч.* Кайгы-хәсрәттән һ.б.дан бушандыру. *Ничек аның алдына ятып, үземнең кайнар яшьләрем берлә башымдагы кайгыларымны, хәсрәтләремне юармын!* Г.Исхакый

8) *күч.* Җинаятьчел ысуллар белән табылган акчаларны рөхсәт ителгән, рәсми, законлы эшчәнлек алып барган оешма яки предприятиегә кертеп законлаштыру, легальләштерү. *Телевизорны һәр көн карап барган кеше булагак әйтәм, алар еш кына безнекеләрне дә эләктерәләр: я акча юган, я ришвәт, я корал саткан өчен.* Д.Гыйсметдин. *Гөнаһысына керәсе килми, шулай да акча юуның нәкъ менә дәүләт заказлары аша җиңел эшләнүе сер түгел.* Ватаным Татарстан

9) *күч. сөйл.* Яңа алынган яки яңа ясалган, төзелгән берәр нәрсәне котлап мәҗлес оештыру, эчү; тахильләү. *– Кызым, бар, Мирхәйдәр бабайны чакырып кер, – диде әнисе. – Дипломыңны бөтен авыл белән «юыйк» әле.* М.Яһудин

◊ **Юган (юып алган) кебек** 1) Бик чиста, бер генә тап та булмаган (өслек, өсйөз тур.) *Күк йөзе юып алган кебек чип-чиста.* Г.Әпсәләмов; 2) Һич тә булмаганча, әсәре дә калмыйча. *Баш авыртуы юып алган кебек беткән, зиһене чиста иде аның.* М.Галиев. **Юып куйган кебек** *к.* **юган (юып алган) кебек**. *Юып куйган кебек җитен кыры Дулкынлана күрән диңгез булып.* Ә.Ерикәй

**Юа бару** Һәрберсен, булган берсен юу. *Эре су тамчылары тирән җәрәхәттән аккан кан эзен бетереп юа бардылар...* Казан утлары

**Юа башлау** Юарга керешү. *Зур ай да минем күңелемне үзенең яктылыгы берлә юа башлады.* Г.Исхакый

**Юа бирү** Юуын һаман дәвам итү. *Ул әлеге кара савытын юа да юа бирде.* Ә.Гаффар

**Юа төшү** Тагын да бераз юу. *Кулларыңны юа төш*

**Юып алу** Тиз генә юу. *Бушап калган машинасының ишекләрен, капкачын ачып, су һәм чүпрәк алып, тимер атының астын-өстен, эчләрен юып ала.* А.Нәҗми

**Юып бетерү** Ахырга кадәр, тулысынча юу. *Урман юлын сугыш алдыннан гына вак таш җәеп, тракторлар белән таптатып ныгытканнар иде, хәзер аның да күп җирен яңгыр, кар суы юып бетерде.* А.Гыйләҗев

**Юып кую** Алдан юу; юып әзер хәлдә калдыру. *Әнисенең аяк тавышлары тынуга, Һади ипи белән сөтне ялт иттерде дә салкын су белән генә чынаяк чокырын юып куйды.* А.Гыйләҗев. *Аш бүлмәсендәге өстәлгә сезнең өчен җиләк-җимеш юып куйдым.* Х.Ширмән

**Юып чыгу** Тулысынча, башыннан ахырына кадәр юу. *Зөһрә тиз-тиз генә идәнне юып чыкты.* Н.Фәттах

**ЮУЧЫ** *и.* **1.** Юу, чистарту, җыештыру белән шөгыльләнүче кеше. *Мәнмүрә ике бала өчен ана, идән, кер юучы, ашарга пешерүче генә булмады, ир-ат*

*өстенә йөкләнелгән барлык авыр эшләрне үзе алып барды.* М.Әхмәтшина

**2.** *с. мәгъ.* Юу, чистарту, җыештыру белән шөгыльләнгән. *Тик Латыйфаны юучы карт карчыклар, тәненең бер исән җире юклыгын күреп, телсез калдылар.* З.Кадыйрова

**ЮФТЬ** *и. фар.* Аяк киемнәре тегү, ат дирбиясе ясау өчен ат, сыер, дуңгыз тиресен май һәм дегет белән эшкәртеп иләнгән йомшак күн. *Күнне сәнгатьчә эшкәртү, сафьян һәм юфть дип аталган йомшак күннән затлы әйберләр, шул исәптән аяк киемнәре тегү белән әле борынгы бабаларыбыз – Идел буе болгарлары ук таныган булган.* Казан утлары

**ЮХА** *и.* **1.** 1) *миф.* Йөз яисә мең ел яшәп, чибәр хатын-кыз рәвешенә кереп, үзе бик ягымлы булып күренсә дә, кеше йоклаганда канын суырып хәлсезләндерә, авыруга әйләндереп үтерә дип күзалланган елан рәвешендәге мифик персонаж. *Елан, йөз яшенә кадәр яшәсә, аждаһага әверелә, мең яшькә кадәр яшәсә, юха була, имеш.* Миф. *Юха булгач, ул җен, пәри кеби булып, төрле сыйфатларга керә ала, имеш, ди...* Г.Ибраһимов

2) Ялагай, икейөзле, ялганчы кеше. *Бигрәк тә юха инде сез, иеме? Шулкадәр ялагай булырга кирәк бит, әй!* Р.Батулла. *Тегесе дә юха аның, «башкайларым чатный, үләм!» дип кызгандыра белә.* Л.Хәмидуллин

3) *күч.* Куштанлыгы һәм чибәрлеге белән алдалап, кешене үз файдасына хезмәт иттерә, үзенә карата торган хатын-кыз. *Беләм мин ул Рәдинә дигән юханы.* Р.Мулланурова

**2.** *с. мәгъ.* Ялагай, икейөзле һәм ялганчы. *Синең юха телеңә ышанып, тынычлыгымны җуйдым...* А.Гыйләҗев

**3.** *рәв. мәгъ.* Ялагайланып, икейөзләнеп. *– Бату хан агаем! – дип, бик кадерле туганына эндәшкәндәй юха башлады ул.* В.Имамов. *Әйтәм аны, бик юха кыландылар, апакаем да, алмакаем, имеш.* Д.Булатова

◊ **Юха елан** *к.* **юха**. *Ю-юк, әни, аны исән калдырырга ярамый, ул – юха елан, тагын чагарга уңай вакыт көтеп йөреячәк.* А.Гадел

**ЮХАЛАНУ** *ф.* Юхалык күрсәтү, икейөзлеләнү, ялагайлану. *Котлы Яранның кайсы урамыннан гына үтмәсен, һәр капка каршында аны [Миңнеханны] бүрек салып, юхаланып каршылыйлар иде.* В.Имамов

**Юхалана башлау** Юхаланырга тотыну. *Ул тегеләй-болай боргалана, суга батучы саламга ябышкандай юхалана башлады.* Р.Кәрами

**Юхаланып алу** Берникадәр юхалану. *– Юк инде, нишләп кешегә сөйләп йөрсен! – дип юхаланып алды Шәмсия.* Ф.Сафин

**Юхаланып тору** Әле, хәзерге вакытта юхалану. *Синең дә кем икәнеңне беләбез. Әйтмим генә. Юхаланып торасың монда!* М.Кәрим

**ЮХАЛЫК** *и.* Юха булу, икейөзлелек, ялагайлык. *Юньсез юхалыкны да булдыра алмас.* Мәкаль

**ЮШ** *хәб. сүз* Ярашлы, тәңгәл, туры килеп тора. *Ефәк пута билгә буш, Сатин казакига юш.* Җыр. *Ул – би, аның сүзе монда юш, ләкин ялгыш алай-болай Мәмлине яклау белдерсә, соңыннан аның күзен дә ачтырмаячаклар.* Н.Фәттах

◊ **Юш булу** *к.* **юш килү**. *Мусаның Казанга килүе хуш булды һәм юш булды.* Ш.Маннур. *Хуҗа, эшең уң булсын, Теләгәнең юш булсын, Күңелләрең хуш булсын, Нәүрүз котлы булсын!* Г.Макаров. **Юш килү** 1) Дөрескә чыгу, чынга әверелү. *Юраганы юш килеп, Таһирга биш яшь тулгач, Баһир вәзир вафат була.* Дастан; 2) Туры килү, ярашлы булу. *Шушындый көннәрнең берсендә Алмыш ханның күңеленә юш килгән тагын бер яңалык булып алды.* Н.Фәттах

**ЮША́У** *ф. диал.* Күшәп яки ял итеп бер урында яту (көтүдәге мал-туар тур.). *Аргамак атның билгесе – аз утлар да күп юшар, азамат ирнең билгесе – аз сөйләр дә күп тыңлар.* Мәкаль

**ЮШКӘ** *и. рус* Мич юллыгын томалый торган тимер клапан. *Ул тәрәзәләрнек ябылганмы дип карады, морҗа юшкәсен тикшерде, күзге өстенә ал яулыгын ташлады.* А.Гыйләҗев

**ЮШКЫН** *и.* 1) Су кайнаган савытның стенасына утырып калган минераль тоз катламы. *Сыешлыкларга утырган юшкын калын-калын кисәкләр булып кубып төшә иде, шуңа да, җаена төшеп алгач, эш ырамлы барды.* З.Мурсиев

2) Утырган ләм, ком. *Ташкыны кайтса да, юшкыны калыр.* Мәкаль. *Яр буенда саз да таллык, ауган агач, Юлым бүлеп калка юшкын өркәчөркәч...* И.Диндаров

3) Судагы болганчыклык, куерык, ләм. *Ага ташкын, ургый юшкын, Упкын шавы – язлар килде.* М.Шиһапов

4) *күч.* Күңелдә, хәтердә калган авыр хис, начар тәэсир. *Бәгырьләрдәге туң юмарт кояш җылысында эреде, күңелләрдәге юшкын кар сулары белән агып китте.* В.Нуриев. *Алсу бит алмасы буйлап тәгәрәгән яшьләре кибәргә өлгерсә дә, күңел төпкеленә утырган юшкын әле дә булса юылмаган кебек.* А.Әхмәтгалиева

**ЮЫЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **юу**. *[Малай] Өстенә еш юылудан һәм алмашы булмаудан сизрәп, муртаеп беткән кызгылт киндер күлмәк, кыска киндер ыштан кигән.* А.Хәлим. *Бүлмәнең идәне чиста иттереп юылган.* А.Гыймадиев

2) *күч.* Кояш, җил, яңгыр тәэсире белән ашалу, уңу, төсе китү. *Баш очына кагып куелган агач күптән череп янтайган, гүр иясе Халисәнең исеме юылган.* Р.Батулла

3) *күч.* Агымсу, җил, яңгыр тәэсирендә ашалу, яргалану, җимерелү, кушлану; эрозиягә бирелү. *Татарстанда Кама Тамагы районы территориясендә Иделнең уң як ярында урнашкан Сөйке, Юрьев мәгарәләре гипс катламнары юылу аркасында барлыкка килгән.* Ф.Гарипова

4) *күч.* Югалу, бетү, юкка чыгу. *Еллар узу белән, аның исеме, фамилиясе хәтердән юылырга мөмкин.* Т.Галиуллин

5) *күч.* Гаеп, гөнаһлар кичерелү. *Яшь белән гөнаһ юылмый.* Мәкаль. *Ә илче Бәгүрнең гомерен кыя калсаң, инде син үзең дә гомер юылмаслык хата кылачаксың.* В.Имамов

6) *күч.* Законсыз табылган байлыкны легальләштерү. *Русиядә ярымкриминаль юл белән табылган, юылган акчалар көнендә, сәгатендә диярлек Лондонга, Швейцария банкларына, Француз Ривьерасына китә торалар.* Н.Шәрифуллин

**Юыла бару** Торган саен күбрәк юылу. *Шәһәр якынаймады. Атлаган саен тоныклана, сыегая, юыла барды.* Р.Батулла

**Юыла башлау** Юылуга табан бару. *Башта ул [Җиһан әби] картлыктан җетелеге юыла башлаган күз карасы белән сәерсенеп, шикләнеп карады.* Г.Гыйльманов

**Юыла тору** Һаман, бертуктаусыз юылу. *[Агыйделнең] Ярлары да кеше гомере сыман, кителеп-кителеп кенә юыла тора, юыла тора...* М.Шабаев

**Юыла төшү** Бераз юылу; тагын да юылу. *Баштарак ул үзенең бу халәтен төгәл генә аңлый алмады, әмма тора-*

*бара карт аңындагы томанлы хисләр пәрдәсе юыла төште.* Г.Гыйльманов

**Юылып бетү** Тәмам, бөтенләй, тулысынча юылу. *Аның өчен чынбарлык белән хыял чикләре тәмам юылып беткән.* Г.Гыйльманов

**ЮЫНГЫЧ** *и.* Эченә су салып, борыныннан аз-азлап су агызып юыну өчен махсус савыт. *Исмәгыйль кыска кунычлы киез итекләре белән йомшак кына атлап бүлмәсеннән чыкты да, бисмилласын әйтеп, юынгыч астында бит-кулларын чылатырга кереште.* Л.Ибраһим-Вәлиди

**ЮЫНДЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **юыну**. *Суд алдыннан бер юындырганнар иде, шуннан бирле тән су күрмәгән.* И.Салахов

2) Кемне дә булса юу. *Йом күзең, улым!.. Йокыңнан торгач, йомшак күбекле, хуш исле суда юындырырмын үзеңне...* А.Гыйләҗев

**Юындыра башлау** Юындырырга керешү. *Әйдә, балакаем, җитте, юындыра башлыйм үзеңне.* Г.Галиева

**Юындырып алу** Тиз генә юындыру. *Айбикә инәй баланы юындырып алуга, Барый абзый баланың өстенә җылы чүпрәк каплады.* З.Кадыйрова

**Юындырып бетерү** Юындыруны тәмамлау. *[Патшаны] Юындырып бетергәч, Әбү-Сыйр коена торган суга гөлчәчәк суы куша да патшага шул суга керергә куша.* Әкият

**Юындырып тору** Һәрвакыт, гел юындыру; әле, хәзер юындыру. *Имче карчык әйтүе буенча, аны җиде төрле кыр чәчәге суында җиде көн тоташ юындырып торганнар.* Г.Гыйльманов

**ЮЫНТЫ** *с. к.* **юынтык**. *Идәннең урта бер җирендәрәк, чокырланып торган бер төшендә, әрлән төннеге сыман тишек күренде. – Юынты сулары шуннан агып китә, – диде Ямгырчы би, аңлатып.* Н.Фәттах

**ЮЫНТЫК** *с.* **1.** Нәрсәне дә булса юганнан соң калган (су һ.б. сыеклыклар тур.). *[Унөч] Пешекченең юынтык суларын түгә, бәрәңге әрчи, утын кисә, ашый-эчә бу туйганчы, тазара.* Әкият

**2.** *и. мәгъ.* Юганнан соң калган су, ташландык су. *Искергән дип, ярты ипине күз дә йоммыйча юынтык чиләгенә ташлый...* А.Гыйләҗев

**ЮЫНУ** *ф.* Үз-үзеңне, бит-кулыңны, тәнеңне юу. *Умарта кортлары кеше тәнендәге тир, одеколон һәм аракы исләрен яратмыйлар. Умарта янына чыкканда шуңа күрә ул юынып, чистарынып чыга.* М.Мәһдиев

**Юына башлау** Юынырга керешү. *Ул, кушучлап су чумырып алып, шаяракөлә юына башлады.* А.Гыйләҗев

**Юынып алу** Тиз генә юыну. *Әйдә, юынып ал да чәй өстәленә җитеш.* Г.Гыйльманов

**Юынып бетү** Юынуны тәмамлау. *Юынып бетеп коенгач, икенче бүлмәгә чыктык.* И.Салахов

**Юынып йөрү** Әле, хәзерге вакытта юыну. *Әле юынып йөри, ишетми мине.* М.Хуҗин

**Юынып тору** Һәрвакыт, гел юыну; әле, хәзер юыну. *Мин көн дә бик шәпләп юынып торам.* Казан утлары

**ЮЫРТТЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **юырту**. Атны юл буе юырттыру

2) *сөйл. к.* **юырту**. *Без менә шул авылга шәп кенә юырттырып, дәртле кыңгырау тавышы белән сәламләп килеп кердек...* Ә.Еники. *Ханның мичәүләп җиккән атлары җилле генә юырттырып, кирмәнгә керделәр.* М.Хәбибуллин

3) *күч.* Җиңел, җитез, тигез хәрәкәтләр белән чабу, йөгереп бару. *Җиңги мичкә яга, иртәнге аш әзерли торган арада, мин юырттырып кына су алып кайтам, чөнки инде кар яуган, фляганы үземнең үрәчәле кечкенә чанага утыртып йөрим, ә чана арбага караганда күп җиңел ул.* В.Нуруллин

**Юырттыра башлау** Юырттырырга тотыну. *Безнең агай да, дилбегәсен кагып, атларын юырттыра башлады.* Ә.Еники. *Такыр юлдан ат иркенләп, җиңеләеп юырттыра башлады.* Н.Фәттах

**Юырттыра төшү** Ныграк юырттыру. *Атларны юырттыра төшик, юкса караңгыга калабыз*

**ЮЫРТУ** *ф.* 1) Алгы уң аягы белән арткы сул аягын берьюлы һәм алгы сул аягы белән арткы уң аягын берьюлы алмаш-тилмәш алга ташлап чабу (ат тур.). *Малкай да нидер сизенәме, югыйсә һич куаламый да бит үзен, ә ул гел юыртып бара.* Г.Галиева

2) *күч.* Тиз-тиз йөгергәләп йөрү, йөгергән шикелле атлау. *Юл белән йөрсәң юыртып йөр; юыртып йөрсәң, юл ырар.* Мәкаль. *Ул йорт белән мунча арасында юыртып йөргән чакта, җир өстенә караңгылык ятты.* В.Имамов

**Юырта башлау** Юыртырга тотыну. *Авылны чыгуга, кечкенә чаптар бия томырылып юырта башлады.* М.Гали

**Юырта төшү** Тагын да шәбрәк юырту. *Атларны юырта төшәбез, алдыбызда Чакматаш иңкүлеге җәйрәп ята.* Казан утлары

**Юыртып китү** Юыртырга тотыну. *[Колын] Әй берзаман муенын кәкрәйтеп, койрык чәнчеп, төп-төз аяклары белән тып-тып басып юыртып китә, агай! Колаклар шәмрәйгән, күзләрендә ут!* Г.Бәширов

# Я

**Я** I (**ягез, ягезче**) *ы.* **1.** 1) Эндәшү, мөрәҗәгать итү, берәр эш-хәрәкәткә өндәү, әйдәү яисә үтенечне белдерү өчен кулланыла; әйдә. *Я, кадерле кунак, рәхим итеп табынга борылып утыруыгызны үтенәм.* А.Алиш. *Ягез әле, туташ, без әфәндегезгә дә бер җырлап күрсәтегез, булмаса!* Ә.Еники

2) Әңгәмәдәшнең фикерен беләсе килгәндә, сүзен дәвам итүен теләгәндә, үтенгәндә, сөйләвен, җавабын ашыктырганда кулланыла; хуш. *Я, ничек урман эше, Газзән абый?* Г.Әпсәләмов

3) Эш-хәлдән ризасызлыкны белдереп, әңгәмәдәшен оялту, битәрләү, канәгатьсезлек күрсәтү өчен, сорау җөмләдә кулланыла. *Я, бу юлы ничек акланырсыз инде?* Җ.Фәйзи. *Я әйт, нәрсә өчен дип үстерә инде бу мыекны?* Р.Мөхәммәдиев

**2.** *кис. мәгъ.* 1) **я инде, я сәнә**. *Инде, сәнә* сүзләре белән килгәндә үтенеч, ялыну төсмере өсти. – *Я инде, бер сызып җибәр, – дидек без, сабырсызланып, – «Галиябану»мы шунда, «Авыл көе»-ме, «Наласа»мы, анысын үзең беләсең.* А.Расих. – *Я сәнә!.. – диде җизнәсе канәгатьсезлеген белдереп. – Үз-үзеңә ясин чыгып утырмачы, зинһар.* М.Хәсәнов

2) **я әле**. Эндәшү һәм өлешчә боеру төсмерен белдерә. *Бикчәнтәй агай, я әле, булмаса, тутыккан күңелләрне нечкәртеп, уйнап, җырлап җибәрегез.* Т.Гыйззәт. *Әйдәсәнә, әйдә әле, кызлар шикелле кыстатма, я әле, ашап кына утырсана әле...* Г.Бәширов

**Я** II *ы. гар.* Эндәш сүзләр алдыннан килеп, мәгънәне көчәйтү өчен кулланыла; и. *Аның: «Я Алла, әллә мәңгегә күзеңне йомдыңмы дип, котларым бер дә калмады», – дип әйткәнен хәтерлим.* Г.Галимуллина. *Артыннан кемдер килүен абайлап, борылып караса: я раббым – Ул!* Г.Галиева

**Я** III *терк. к.* **яки, яисә**. *Тегеләр аның сүзләрен тыңлый-тыңлый арып бетәләр я бөтенләй тыңламый ташлап китәләр икән.* А.Алиш

**ЯБАГА** *и.* **1.** Хайваннарның язга чыккач коела торган йоны. *Ат яисә сыер ябагасын тараганда, тигез, шома сап, шулай итеп, кулда шуышып, әйләнгәләп тормаячак.* Н.Фәттах. *Вакытында ашатмый, эчертми, өсте ялык-йолык килеп торырлык булганчы ябагадан чистартмый, алашабызны җәен тарантаска, кышын кошевой чанага җикмәдем.* А.Хәсәнов

**2.** *с.* Бер язда туып икенче язга чыккан, әле йонын коймаган; икенче яшькә чыккан; бер яшен тутырган (колын, ат тур.). *Житәр, энем Сиражҗи, алама кешенең теле ачы, ябага тайның бете ачы, дигәндәй, бер нәрсә булса, сыткы сагыз кебек, кешегә ябышасың.* Т.Гыйззәт. *Буразнага керергә ярамаган трактордан ябага атның яхшырак икәнен аңладым.* Ф.Баттал

**ЯБАГАЙ** *с. монг.* **1.** Ярлы, фәкыйрь, хәерче. *Юк, көчлеләр кирәк, ярлы булсын, ябагай булсын, көчле булсын – Хәсәннәр кебек, Морат ишеләрдәй.* Х.Хәйруллин. *Егет, имеш! Ябагай йолкыш! Анаң белән бергәләп ычкыныгыз!* М.Хуҗин

**2.** *и. мәгъ.* Ярлы, хәерче кеше; түбән катламнан булган кеше. *Ялгышкандыр: миндәй ябагайга ярашырлык ярлы юк, дисә.* З.Мансуров

**ЯБАЙ** *с. фар. диал.* **1.** 1) Кечкенә, арык, мескен. *Әүвәле, баһадир булам дип, ябай әтәч булып йөргәнмен.* Г.Каюмов

2) Кыргый, токымсыз, гади. *Ябай ат*

3) Гади, затсыз, үзенә җәлеп итми торган. *Шушы ябай чырайда нинди гүзәллек булсын?* Р.Батулла. *Ябай кызлар белән уйнап, хихылдап йөрергә тиеш түгелсең.* Г.Каюмов

4) Ярлы, гади, тыйнак. *Гади, ябай табын, әмма күпме ихлас кызыксыну, эчкерсезлек, җылы хисләр бар аларның мөнәсәбәтендә.* Т.Әйди. *Ә инеш елгасының икенче ягы, янында ухылдаган бу ерткычның тавышын ишетмәгән, сулышын тоймаган да кебек, үтә гади, ябай үз тормышы белән тик яшәп ята сымак...* Л.Ибраһим-Вәлиди

**2.** *рәв. мәгъ.* Ярлы хәлдә; начар итеп; гади рәвештә. *Кемнәрдер ак күлмәкләрдән чират көткәндә, чәчәк бәйләмнәренә күмелгәндә, шампанскийлар атканда, ябай киенгән кияү белән кәләш ашыгып кына имза куеп чыктылар, Мендельсон музыкасын тыңлап.* К.Кара

**ЯБАЙЛЫК** *и.* Гадилек, тыйнаклык. *Якташларымның ябайлыклары, Күңелләренең әй байлыклары...* Р.Миңнуллин

**ЯБАЛАК** *и.* **1.** 1) *зоол.* Ябалак кошлар семьялыгыннан зур күзле, ыргаксыман томшыклы, йомры башлы төнге ерткыч кош; *русчасы:* **сова**. *Береазданул, ябалак тавышына күнегә төшеп, бетмәс-төкәнмәс хатирәләргә чумды.* А.Расих. *Төнге тынлыкны ярып кычкырган ябалакларга да игътибарын юнәлдерми горур кыз.* А.Нәҗми

2) *күч. тирг.* Игътибарсыз, оешмаган, таркау, эш рәтен белми торган кеше; күзле бүкән, ачыгавыз. *Әй, ябалак, әйтәм ич, зур придан белән, дип.* К.Тинчурин. *Мәзин үзенең хатынына һәм башкаларга ахмак, хәшәп, надан, ябалак дип эндәшә.* Н.Фәттах

**2.** *с. мәгъ.* Мамык кебек җиңел һәм күпереп торган эре бөртекле. *Әллә ни арада гына салкын җил исә башлады, күк йөзен ябалак кар каплады.* М.Мәһдиев. *Сирәк-мирәк кенә төшкәләгән ябалак кар астында тоныкланып юкка чыга барган машина эзе тиздән биек коймалы мәһабәт йорт каршына килеп туктады.* Г.Гыйльманов

◊ **Ябалак күз** Игътибарсыз, гамьсез яисә артык ашыгып, ашкынып йөргәнгә күрә аны-моны күрмәгән, сизмәгән кешегә ачуланып әйтелә; акай күз. *Ябалак күз! Бир яулыгымны!* К.Тинчурин. – *Әйтерсең эштә түгел, әнисе йортында утыра, ябалак күз, – дип үртәлде ул.* З.Фәйзи. **Ябалак шулпасы** Исерткеч эчемлек. *Әтисез үскән бу чибәр кыз, әле күптән түгел генә күрше авылның ябалак шулпасы ярата торган бер егетенә кияүгә чыгып, бик тиз әйләнеп тә кайткан иде.* Ә.Хәсәнов. *Шулай бервакыт, безгә, ягъни идарәгә, ябалак шулпасы (Шәледә кайберәүләр исерткеч сыраны шулай дип атыйлар) эчеп, яхшы ук җилләнгән Сәхәветдин абый Сәйфетдинов килеп керде.* Ватаным Татарстан

**ЯБАЛАКБАШ** *и. зоол. к.* **ябалакчык** (*2 мәгъ.*). *Әлбәттә, моның да чиге бар: бакалар дөге үстерелә торган басуларда дөгенең дошманы ябалакбашны ашыйлар.* М.Мәһдиев

**ЯБАЛА́К КОШЛАР** *и. зоол. күпл.* Ябалаксыманнар отрядыннан мәче башлы ябалак, байгыш, йокычан ябалак һ.б. төрләрне берләштерә торган семьялык; *русчасы*: **совиные**. *Ябалак кошлар семьялыгындагы иң эре кошларның берсе – байгыш, ул бөркеттән кечкенәрәк, ак ябалактан зуррак.* Э.Сафина

**ЯБАЛА́КСЫМАННАР** *и. зоол. күпл.* Зур күзле, кабарып тора торган йомшак каурыйлы, төнлә ауга чыга торган ерткыч кошларны берләштерүче отряд; *русчасы:* **совообразные**. *Әлеге белешмәдә ябалаксыманнар отрядына кергән 200 эре һәм уртача зурлыктагы ерткыч кошларга характеристика бирелгән.* Э.Сафина

**ЯБАЛАКЧЫК** *и. зоол.* 1) Ябалак кошлар семьялыгыннан урманнарда, саванналарда, далаларда яши, күбесенчә бөҗәкләр белән туклана торган соры төстәге зур булмаган ерткыч кош; *русчасы:* **совка**. *Елга иseme кергән атамалар: Уссури ябалакчыгы, Амур ягылбае, Амазонка тутый кошлары, Амур кече күлбугасы.* Фән һәм тел

2) Ябалакчыкчалар семьялыгыннан кортлары авыл хуҗалыгы культураларына зарар китерә торган коңгырт төстәге төнге күбәләк; *русчасы:* **совка**. *Ләкин, ябалакчык, кәбестә күбәләге, алма күбәләге кебек корткычлар белән бергә, кайбер файдалы бөҗәкләр дә юкка чыга.* Яшь натуралистларга

**ЯБАЛАКЧЫ́КЧАЛАР** *и. зоол. күпл.* Бөтен кыйтгаларда да очратырга мөмкин булган, аеруча кичен һәм төнлә актив тереклек алып бара торган соргылт көрән төстәге, уртача зурлыктагы күбәләкләрне берләштергән семьялык; *русчасы:* **совки**

**ЯБАЛДАШ** *и.* Агач кәүсәсе башында тармакланып, куе булып үскән ботаклар. *Кире урман юлына чыкканда, баш очларыннан, киң канатлары белән имән ябалдашларына тия язып, зур бер кош очып үтте.* М.Маликова. *Көн кичкә авышкан инде, кояш яктысы юан кәүсәле карамаларның калын ябалдашлары каплаган туплауның кара көзгесендә куерып, саранланганнан-саранлана бара.* А.Хәлим

**ЯБАЛДАШЛАНУ** *ф.* 1) Бик күп ботаклар чыгарып, киңәеп, тармакланып китү (агач тур.). *Безнең бакча исә үзебез Әлмәттә яшәгән арада нык куерган, алмагачлар ифрат та үсеп, ябалдашланып күкне томалаган, күләгәләгән – яшелчәгә әллә ни уңайлык калмаган.* Б.Рәхимова. *Утыртасы агачлар утыртылып ябалдашланган, балалар үсеп җитеп дөнья кендегенә тоташтырылган, салынасы йорт-диварлар салынган.* Р.Фәйзуллин

2) *куч.* Тармаклану, җәелү, артып, үсеп китү. *Аның күргән-белгәннәре, кичергәннәре хакында сөйләүгә күчкәнче, нәсел-нәсәбәсе, ата-ана, әби-баба ягыннан киң тармакланып, ябалдашланып үскән, тирән тамырлар җибәргән шәҗәрәсе белән танышып китү кызыклы булыр кебек.* Р.Корбан

**Ябалдашлана бару** Торган саен ныграк ябалдашлану. *Тирәк ябалдашлана бара*

**Ябалдашлана башлау** Ябалдашлану билгеләре күренү. *Без утырткан агач та ябалдашлана башлаган инде.* Р.Вәлиева

**Ябалдашланып бетү** Бик нык ябалдашлану. *Бик нык үсеп киткән, ябалдашланып беткән ул агач өйгә көн яктысын үткәрми диярлек.* Ватаным Татарстан

**ЯБАЛДАШЛЫ** *с.* Ябалдашы булган, ябалдашланып торган. *Моназыйрның карашы элеккеге мәчет мәйданына текәлгән булса да, ул андагы ак кирпеч бинаны да, юан тупылларны да, җәенке ябалдашлы талларны да күрми иде.* М.Хуҗин. *Кышкы табигать бигрәк матур, дип уйлыйм мин, күзләремне дә ала алмыйча, ак каеннарга, ябалдашлы наратларга, киң итәкле яшел чыршыларга карагaнда.* Р.Рахман

**ЯБГУ** *и. тар.* Кайбер төрки дәүләтләрдә ханнан соң икенче зат, югары дәрәҗәдәге хаким; хөкүмәт башында торучы зур түрә. *Егерме биш хатыны, алтмыш кырнагы булган кырык җиде яшьлек Җөфүт каган Алмыш ханның кызы Аппакны – угыз ябгусының сеңелесе Айкын хатыннан туган гүзәл Аппакны – үзенә егерме алтынчы хатынлыкка сораган иде.* Н.Фәттах. *Хәзерге Көнбатыш Казахстан җирендә яшәүче угызларда гаскәр җитәкчесе Әтрәкнең сүзе аларның башлыгы – ябгу сүзеннән үтемлерәк булган, ә ул исә Болгар патшасы белән туганлашкан һәм исламны кабул итүгә каршы килмәгән.* Р.Хәкимов

**ЯБУ** I *ф.* 1) Этәреп, төшереп, каплап һ.б.ш. юллар белән нindидер ачыклыкны томалау. *Урындык аркасына эленеп торган кызгылт пакетка китапны тыкты, тавыш-тынсыз гына ишекне ябып, бүлмәдән чыкты.* А.Хәлим. *Кинәт исенә килеп, ашыгып-кабаланып тәрәзәләрне ябарга кереште.* Г.Гыйльманов

2) Берәр әйбернең өстен капкач яки башка берәр нәрсә белән каплау, томалау. *Машинабыз бер чокырдан чыгып икенчесенә төшкән чагында, савымчылар ныклап беркетмичә йокы аралаш кына япкан капкачлардан сөт бөркелеп, чалбарыбызны, ә кызларның итәкләрен юешли.* К.Кәримов. *Чү, башта бу чиләкнең капкачын ябыйк, Сәлимә.* Н.Гыйматдинова

3) Кем яки нәрсәнең дә булса өстенә, ачык урын калдырмыйча, берәр әйбер җәю, каплау, бөркәү. *Аннары ул малайның җиңел юрганын рәтләбрәк япты, яшь математикның тыңлаусыз чәченнән сыйпады да караваt янындагы яшькелт торшерны сүндерде.* А.Тимергалин. *Тәскирә, акрын гына кузгалып, сак кына тотып, кызының башын тау кебек өелеп торган мендәрләр өстенә күчереп куйды, өстенә шәльяулыгын япты.* Г.Гыйльманов

4) Авыз, күз кебек ачыла-ябыла торган әгъзаларны ачылганчыга кадәр булган хәленә кайтару. *Авызыңны ябарга да өлгермәссең, хан бабаңның мирасыннан колак какканыңны сизми дә калырсың.* Д.Салихов. *Алайса ник үзең дә күзләреңне япмыйсың?* Г.Гыйльманов

5) Җәелгән, ачылган, таратып куелган нәрсәне кире җыю, каплау. *Ниһаять, Мансур да китабын япты, аяк очларына гына басып, юыну бүлмәсенә чыкты.* Г.Әпсәләмов. *Мин инде, болардан соң миңа сөйләр сүзе калмагандыр дип, блокнотымны япкан идем.* М.Мәһдиев

6) Яшерү, күрсәтмәү максаты белән, күренмәслек итеп махсус каплау. *Күлмәк чабуларың Аякларыңа кыстың. Күкрәкләрең тиз-тиз ябасың, Ашыгаашыга үзең барасың.* Х.Камалов. *Бер өйгә битләренә кара капрон оеклар япкан ике бандит бәреп керә.* Т.Галиуллин

7) Кемне яки нәрсәне дә булса бина, корылма һ.б.ш. эченә кертеп калдырып, чыгу юлын каплау. *Гөлфия сыер савып, сарыкларны ябып керде дә план язарга утырды.* Р.Айзатуллин. *Хәлим сыерларны лапаска ябарга булышты.* Г.Гыйльманов

8) Йозак, ачкыч һ.б.ш. белән бикләү (бина, корылмалар тур.). *Рәмзия: – Мөниржан абый, бүгенгә җитеп торыр, кибетне ябам, – дигәч кенә туктады һәм үзенең арыганлыгын сизде, җәрәхәте дә сыкрый иде.* Н.Әхмәдиев. *Мәктәпне ябып кайтып китәргә җыенган вакытта килде ул, бер сәгать чамасы сөйләшеп утырдык.* М.Вәлиев

9) Нинди дә булса корылманың өстенә япма, түбә ясау. *Таһирлар, мунчаның сайгакларын җәеп бетереп, түбәне ябарга керешергә җыеналар иде.* А.Хәсәнов. *Хәзер инде аңа беренче көннәрдәгегә караганда күбрәк түли башладылар, курчак өйнең, ниһаять, түшәмен яптылар, эчке җиһазларын яхшырттылар.* А.Азимов

10) Басу, күмеп китү, билгеле бер урынны, җирлекне тоташ каплау (үлән, кар, тузан һ.б. тур.). *Һәр таң урап кайтыр юлларымны Юка гына кырпак кар япкан.* Р.Бикбаев. *Ачы җилләр исә салкын яктан... Күл өстен дә инде бозлар япкан...* Ф.Фәтхи

11) Яктылык чыганагын, күк йөзен тоташ томалау. *Инде күптән кояш күренгән юк, Күкнең йөзен болыт та япты.* Ф.Яхин. *Әнә бит, кичке эңгермеңгергә вакыт ерак булса да, авыл өстен куе томан япкан.* Г.Гыйльманов

12) Кереп-чыгып яки үтеп йөрү юлын бикләү, ябу; кая да булса керүне, үтүне туктату. *Сәгать төнге икегә, чикне ябар өчен, чик саклаучылар белән таможенниклар килә.* М.Юныс. *Зур базарлы авыл иде, юл чатында утырган авылны, олы юлны ябып, юл аркылы мәктәп төзеп куйдылар да шулай юлсыз ясадылар.* М.Мәһдиев

13) Нәрсәнең дә булса хәрәкәтен, агышын туктату. *Җибәриек кышны агызып. Елгаларны япты, бикләде ---.* М.Җәлил. *Һәм җавап көтми генә дәвам итте: – Краннарны яптык. Хәзер тынычланыр барысы да.* Ф.Җамалетдинова

14) Кемнедер ирегеннән мәхрүм итү, төрмәгә утырту. *Урларга да ярамый. Тоталар да ябалар.* Т.Миңнуллин. *Бабай, бәхетеңә миңа килеп каптың. Мин булмасам, сине ябалар иде.* Д.Салихов

15) Ирексезләп дәвалау өчен хастаханәгә салу, урнаштыру, озату (мәс., психик яктан тайпылышлы кешене). *Ниһаять, аны акылсызлар йортына ябалар.* Ф.Хөсни. *Күпме яптык инде без үз акылында булганнарны җүләрләр йортына, анда баргач, чыннан да акылыннан яза кеше...* Р.Батулла

16) Авырткан, яраланган урынга берәр нәрсә кую, бәйләү. *Кутыры куба башлаган ярага әрекмән яфрагы япты һәм, кайчандыр ак булган эчке күлмәген ертып алып, җәрәхәтен бәйләде.* И.Хуҗин. *Соңыннан әлеге массаны сөлгегә сылап, йокларга ятар алдыннан, авырткан урыннарга ябам.* Ватаным Татарстан

17) Аркага, җилкәгә салу яки өскә нәрсә дә булса кимичә генә бөркәү; бөркәнү. *Һәнүз Асяның иңнәренә үз пальтосын япты, үзе свитердан килеш, яланбаш кына һава алды.* Х.Хәйруллин. *Әти артыннан коридорга чыктым, өстенә ак халат япкан кара пәлтәсе табиб бүлмәсе янында көзгә чалынып алды.* Х.Ширмән

18) Башка бәйләү. *Алларында ак яулык япкан олы яшьләрдәге бер татар хатынын күргәч, алар аптырап калдылар.* Ф.Бәйрәмова // Алга, билгә бәйләү (алъяпкыч, япма тур.). *Былтыр, алдына ап-ак алъяпкычлар ябып, Әлмәт базарында әтисенә бал да сатышты.* А.Хәсәнов

19) Хатын-кыз йөзен каплау. *Беркөнне ат эчереп кайтам елгадан – юлыма бер кыз очрады. Суга бара бу. Битен япмаган.* Н.Фәттах. *Күзләремне ала алмый тордым Ак пәрәнҗә япкан гүзәлдән.* Р.Вәлиев

20) Нәрсәнеңдер өстен буяу һ.б.ш. белән каплау. *Билен буган киң каеш астында сызма пистоль, көмеш бизәк белән япкан кылыч кыны.* В.Имамов

21) Оешма, предприятие һ.б.ш.ның эшен, эшчәнлеген, хәрәкәтен туктату. *Тик менә мәктәпне ябарга җыеналар шул, авылда балалар җитми.* З.Хәким. *Чөнки милли уку йортларын, беркем белән дә киңәшмичә, ата-аналар фикере белән санашмыйча, бер-бер артлы ябарга керештеләр.* Л.Хәмидуллин

22) Йомгаклау, эшен бетерү, тәмамлау, төгәлләү. *Утырышны ябып, бюро членнарын таратканнан соң, Гадел абый мине үз кабинетына алып керде.* В.Нуруллин. *Җыелышны ябам дигәндә генә Вильданов яңадан сүз сорады: – Бер генә минутка, иптәшләр!* Х.Хәйруллин // Туктату, бетерү, алга таба дәвам итмәү (сөйләшү, фикер алышу һ.б. тур.). *Яптык бу теманы, ишетәсеңме, үзем исән чакта шушы бусагадан да атлап кермәячәкләр.* Р.Хәбибулла

23) Тикшерү, эзләнү барышын алга таба дәвам итмәү, ул юнәлештәге эшчәнлекне туктату. *Прокуратурада, Филатов ялгышмас дип, эшне ябарга булдылар.* З.Мәхмүди. *Бер еллап вакыт узгач, ординатурага обком секретареның кызын алалар, апаның темасын ябалар, апам ординатурадан китәргә мәҗбүр була.* Ф.Бәйрәмова

24) Сезонлы эшләрне, чараларны билгеле бер вакытка кадәр туктату; алда сүз барган өлешен – әлегә кадәр эшләнгәнен төгәлләп кую. *Тагын бер бакча сезонын яптык, күңелгә моңсулык иңде.* Татарстан яшьләре. *Быел 26 нчы сезонны яптык.* Казан утлары

25) *сөйл.* Кайнатып, маринадлап яки башка ысул белән консервацияләү. – *Йөзәр банка компот ябам, кыяр-помидордан салат ясыйм, – ди ул.* Сөембикә. *Җәй җиттеме, кайнатма ясап, салат ябып, кыяр тозлап калырга тырышам.* Ватаным Татарстан

26) Түләп бетерү, тәмам итү, исәп-хисапны өзү, тотылган акча, чыгым һ.б.ш.ны кире кайтару. *Эш тәмамланып, судка җибәрелү сәбәпле, без дә исәп-хисапларны яптык һәм Мәскәүгә озаттык.* Х.Ширмән. *Мин ике көн актарган кәгазь боткасын ул өч минутта карап чыкты һәм болай диде: «Мин ике кредитны ябам».* Безнең гәҗит

27) *диал.* Берәүнең гаебен икенче кешегә сылтау, аудару. *Бер миллион акчаны эшкә тыгабыз, диме! Юк, Тата апага җиткерергә кирәк, я миңа сылтап калдырырлар, сериалларда була бит: тегесе ала, моңа ябалар!* Р.Сәгъди. *Ялгышларын язмышларга сылтый, Гаепләрем аңа ябам, дип.* Р.Мөхияр

28) Карта уенында: көчлерәк карта белән каплау, басу. – *Чү, нишлисең? – Ябам. – Юләр, простой белән козырьны ябалармыни?* Г.Коләхмәтов

29) *куч.* Яшереп калу, чәлдерү, йому; урлау. *Бер атна элек кенә бер казакъның мең тәңкәлек куй маен подвалчы Җамалый белән бергәләп япканнар.* Г.Камал

**Яба башлау** Ябарга керешү. *Аңлашылганча, әсирләрне ниндидер торакка яба башладылар.* Ф.Яхин. – *Саташасыңмы әллә? – дип кычкырды Айсинә, инде яба башлаган ишеген кире ачып.* Н.Көбәш

**Яба тору** Берәр эш-хәлгә кадәр ябу; даими яки әледән-әле ябу. *Табылган, дошман булулары расланганнарны төрмәгә яба торалар.* А.Гыйләҗев. *Яба торалар, артларыннан ачыла бара.* Ватаным Татарстан

**Яба төшү** Бераз ябу. *Фәһимәнең икегә бүленеп үрелгән авыр толымнары, киң маңгаен бераз яба төшкән чәче аның түгәрәк йөзенә бик килешле.* Д.Каюмова. *Каен, яшел чуклы шәльяулыгын хатынның дерелдәгән иңнәренә яба төшеп, калтыранып куйды.* А.Әхмәтгалиева

**Ябып алу** Тиз арада ябу. *Оксана үзенә килешле алъяпкычын ябып ала да: – Мине эзләсәгез, мин монда, кухня якта, – дип аваз сала.* А.Хәсәнов. *Мин тиз генә чыктым да, ишекне ябып алып,*

*ишеккә артым белән торып, ишек шакучы белән сөйләшә башладым*. Сөембикә

**Ябып бетерү** Барысын да ябу, тулысынча ябу. *Бу яңгыравыклы шат көй һәммәсен дә искәртеп уза кебек: – Тәрәзәңне ябып бетермә әле син! – ди шикелле.* Г.Бәширов. *Шуннан соң профессор урыныннан сикереп тора да бераз ачык калган ишекне ябып бетерә башта, аннары, бармагын иреннәренә аркылы куеп, тс-с дигән кисәтү ясый һәм, урынына барып утырып, ашыга-ашыга 5 лене чәпи*. Т.Нәҗмиев

**Ябып җибәрү** Җае белән; берәр нәрсәгә өстәмә буларак ябу. *Түбәләрен ябып җибәргәч, таш пулатлардан бер дә ким булмаячак.* Г.Әпсәләмов. *Шуның өстеннән кечкенә яшел шәл дә ябып җибәрсәңме?* Ф.Бәйрәмова

**Ябып җиткерү** Тулысынча ябу; тиешле дәрәҗәгә китереп ябу. *Ул ишекне ныклап ябып җиткермәгән икән, эчтә сөйләшкәннәре ишетелеп тора иде.* М.Маликова

**Ябып калу** Ябарга өлгерү. *Мәскәү малын ябып калу яңа чыкты*. Г.Тукай. *Нәрсә булмый инде, әллә минем акчаны ябып калмакчы буласыңмы?* Г.Камал

**Ябып килү** Күптәннән бирле әзлекле рәвештә ябу. *Компания безнең илдәге сәүдә нокталарын инде өченче ел рәттән ябып килә, быел исә аларны бөтенләй диярлек бетермәкче*. Татарстан яшьләре

**Ябып кую** Тиз арада яки алдан ябу. *Йөгереп килә дә, шап итеп, әрҗәләрнең өстен үк ябып куя: – Исе дә әрәм булмасын, исе дә!* Г.Бәширов. *Кое авызы җирдән чак кына калку, өстен табаклы тимер белән ябып куйганнар*. А.Тимергалин

**Ябып ташлау** Тиз генә, җәһәт кенә ябу; ялгышлык, кызулык, ачу белән ябу. *Ләкин аның да, башкаларның да зур бәхетсезлегенә каршы, көтелмәгән бер вакытта бу мәктәпне хөкүмәт ябып ташлады*. Г.Ибраһимов

**Ябып тору** Әле, хәзер ябу; вакытлыча ябу; даими ябу. *Капканы ябып торыйк мәллә, атасы?* Т.Миңнуллин. *Ярый әле «светофор» Ябып тора юлларны...* Э.Шәрифуллина

**Ябып чыгу** Барысын да рәттән ябу, барысын да берәм-берәм ябылган хәлгә китерү. *Ирләр абзар-кураларны төзәтмәләр, искергән салам түбәләрне яңа салам белән ябып чыктылар.* М.Галәү. *Су сибәргә килгән хатыннар, бергәләп, электән үк әзерләнеп куелган чыпталар, үрмәләр, әрекмәннәр белән яшелчәләрне ябып чыктылар*. А.Алиш

**Ябып яту** *сөйл. к.* **ябып тору**. *Кыскасы, яңа йортта яңа, матур тормыш башланыр, ә хәзергә әле кемдер тәрәзә яңакларын буяп маташа, кемнәрдер түбә ябып яталар.* И.Абдуллин. *Тагын бер олы гына бинаның түбәсен ябып яталар*. Ватаным Татарстан

**ЯБУ** II *и. иск.* 1) к. **япма** (*2 мәгъ.*). *Сыерга ябу килешми.* Әйтем. *Ябулары яймә алтын, Бар шайманы чын алтын.* Дастан

2) Нәрсәнеңдер эшен, эшчәнлеген туктату, гамәлдән чыгару эше. *Юкса мондый кыскартулар, ябулар – ил күләмендә алып барыла торган сәясәт*. Ватаным Татарстан

3) Кулга алу, тоткын итү, төрмәгә утырту эше. *Бар әйт, таралсыннар, бүген калада бик күп тентүләр, ябулар бара, ди.* Г.Ибраһимов

4) Тоткынлык, әсирлек; хәбес, төрмә. *Уфада да интектерәләр, ябуда тотып газаплыйлар*. И.Юзеев

**ЯБУЛАНУ** *ф. диал. төш. юн. к.* **ябулау**. *Берәүгә бер сүз әйтмичә, азбарга, әле һәммәсе ябуланып, бәйләп куелган тирле атлар янына барды.* Г.Ибраһимов

**ЯБУЛА́У** *ф. диал.* Берәр нәрсә өстенә япма ябу. *Тагы бер чара да кылдылар: көннәр салкын, өшемәсеннәр дип, кунак атларны ябуларга булдылар; әзрәк койрыгы кыркылган кук атка иң зур ябуны биреп, аны да төшеребрәк, киселгән урынны каплабрак куярга киңәштеләр*. Г.Ибраһимов

**ЯБУЛЫ** *с.* **1.** 1) Өсте каплап эшләнгән; өсте ябып куелган. *Бара торгач, юлда, арба юлы олы юлга тоташа торган турыда, юл буендарак ябулы ындыр табагы күренде.* Н.Фәттах. *Өйләреннән куып чыгарып, ябулы машинага утырталар да станциягә алып китәләр.* Р.Габделхакова

2) Нәрсә белән булса да капланган, бөркәлгән. *Өстенә яшел парча җилән кигән Илбарс хан алтын белән көмешкә манган өсте ябулы тәхеттә утыра иде.* А.Тимергалин. *Кесәсеннән ике таблетка-төймә чыгарып, аны йотарга кушты, өсте ак чүпрәк белән ябулы өстәлдән бер стакан су алып бирде.* Ф.Садриев

3) Ябып яки бикләп куелган; ачык булмаган. *Зират коймалары төзек, капкалары ябулы, йөзьяшәр агачлар, мәңгелегеңне онытма дигәндәй, серле шаулап утыралар.* Б.Рәхимова. *Өйнең алгы, аш-су ягы мунча сыман эсселәнгән булса да, тәрәзәләре ябулы кунак ягы ярыйсы гына чамада җиләс иде.* А.Хәлим

**2.** *рәв. мәгъ.* Ябык рәвештә, ябылган килеш, ябылган хәлдә. *Буфеты бер көн ачык, биш көн ябулы була.* А.Хәсәнов. *Лапас эчендә өчме-дүртме бозау ябулы ята.* Г.Гыйльманов // Ябылып. *Атна буе караңгы, кысан таш сарайда ябулы ятып, шушы якты көнне, һавада бөтерелгән сыерчыкларны, әремнән әремгә куна-куна, кырлар буйлап очкан көмештәй ак пәрәвез җепләрен бик сагынган.* Л.Хәмидуллин

**3.** *хәб. функ.* Ябык булу, япкан булу, ябык күренү. *Шылт тавыш юк, Хәтта кошлар очмый, Ишек-тәрәзәләр ябулы.* М.Шабаев. *Төн – йолдызлы шәлен ябулы.* Г.Корбанова

**ЯБУЛЫК** *и. иск. к.* **япма** (*2 мәгъ.*). *Яулык сүзенең татар телендәге мәгънәсенә ябулык сүзе тәэсир иткән.* Р.Әхмәтьянов. *Мендәр итеп ябулыгын Әниләре ипләде. Шактый еллар үтсәләр дә, Сүтелмиләр җепләре.* И.Гыйләҗев. *Ат өстендәге ябулык*

**ЯБЫГАЙТУ** *ф. диал. йөкл. юн. к.* **ябыгу**. *Көндезләрен мәктәпкә йөрү, кичләрен эшләү, төннәрен мәкаләләр язып уяу чыгу, аның ансыз да ябык тәнен ябыгайтканнан-ябыгайта, аның зәгыйфь, чыра кебек йөзен саргайтканнан-саргайта, көчләре кимегәннән-кими бара иде.* Х.Хәмидулла. *Телевизордан балкыган йолдызларга охшарга тырышулар, яңадан-яңа диеталар, ябыгайта торган дарулар, вегетариан кухнясы, яшелчәләр...* Кәеф ничек?

**ЯБЫГАЮ** *ф. диал. к.* **ябыгу**. Кыз ябыгая бара

**ЯБЫГУ** *ф.* Ябык (I) булып калу, тәннең тулылыгы кимү; арыклану, ябык-какча хәлгә килү. *Ябыга, сула, төннәрен йокламый, телсез калгандай, бер кеше белән дә сөйләшми*. Г.Галиева. *Хәтта маңгаена сырлар ятты аның, ак чәчләре күренгәли башлады, шулай ябыкты, кигән күлмәкләре җилфердәп торалар иде.* К.Кара

**Ябыга бару** Акрынлап ябыгу. *Йөзе кайгылы, сабыр, ләкин бу сабыр кайгы аңа бик авырга килә, ахрысы, чөнки ул көннән-көн ябыга бара.* Г.Әпсәләмов. *Әу ул, ни хикмәттер, ябыга бара икән...* Ш.Галиев

**Ябыга башлау** Ябыгырга тотыну; ябыгу билгеләре сизелү. *Мин моны шуннан әйтәм, соңгы көннәрдә безнең сыер күзгә күренеп ябыга башлады*. В.Нуруллин. *Юк, сезгә ярамый, сез кайчан болай ябыга башладыгыз?* З.Кадыйрова

**Ябыга төшү** Бераз ябыгу; тагы да ябыгу. *Бераз ябыга төшкәнгәме, яңак сөякләре калкыбрак тора.* Р.Низамиев. *Тик соңгы вакытта Иршат бераз ябыга төште.* Р.Кәрами

**Ябыгып алу** Тиз арада ябыгу; кыска вакытка ябыгу. *Берара ябыгып алгач, Сиринәгә бик күпләр социаль челтәрләрдә: «Ничек ябыктыгыз? Серегезне әйтегез әле», – дип язганнар.* Сөембикә

**Ябыгып бетү** Тәмам ябыгу; бик нык ябыгу. *– Сереңне миңа гына әйт, югыйсә ябыгып беттең инде, мин беркемгә дә чишмәм, ач сереңне, җиңелрәк булып китәр, – дигән.* Н.Акмал. *Төннәр буе проект төзим дип утыра, юньләп йокы күрми – ябыгып бетте.* М.Маликова

**Ябыгып җитү** Тиешле дәрәҗәдә ябыгу; бик нык ябыгу. *Ябыгып җитеп йөргәндә, җыр ачадыр минем күңелемне.* Г.Рәхим

**Ябыгып калу** Берәр тәэсирдән, вакыйгадан соң ябыгу. *Элек тә какча иде, уразадан соң тагын да ябыгып калды кебек.* Р.Батулла. *Бер төн эчендә Зыятдин карт ябыгып калды, күзләре эчкә батып, болай да юка борыны кылыч кебек тырпаеп чыкты.* Р.Вәлиев

**Ябыгып килү** Соңгы арада акрын гына ябыга башлау. *Кыз күзгә күренеп ябыгып килә*

**Ябыгып китү** Тиз арада сизелерлек ябыгу. *Ябыгып киттең әле бу арада, улым, нинди борчуларың бар соң?* А.Вергазов. *– Ябыгып киткәндәй күренәсең, ашарга җитәме соң? – дип сораштырырга омтылды Зарифа, ике арадагы бозны эретергә тырышып.* К.Кара

**Ябыгып кую** Берәр эш-хәлгә кадәр ябыгу. *Җәй җиткәнче ябыгып куярга кирәк*

**ЯБЫГЫШУ** *ф. урт.юн. к.* **ябыгу.** *Җәй җитәр алдынннан кызлар ябыгыша инде шулай***.** Кызыл таң

**Ябыгышып бетү** Бик нык ябыгу; тәмам ябыгу. *«Ирем эчми...» – дип кайгырып, Ябыгышып бетсеннәр.* И.Юзеев. *«Ашарларына бернәрсәләре калмаган икән», – дип сөйлиләр авылда. Ябыгышып беткәнсез, диләр.* М.Сафина

**ЯБЫК** I *с.* **1.** 1) Тире астында май катламы булмаган; көр булмаган, арык; *киресе:* **симез**. *Болар – сугыш вакытында тылның бөтен авырлыгын үз җилкәләрендә кичергән, йончыган, ябык, сөякчел яшүсмерләр иде.* М.Мәһдиев. *Сәгыйть аның ябык, ямьсез йөзенә игътибар беләнрәк карады, һәм бу йөз аңа беренче мәртәбә элеккечә йомыкый булып түгел, бәлки, матур булып, горур, хәтта кыю булып күренде.* Н.Фәттах

2) Кирәкле тозларга, ашламага ярлы (туфрак тур.). *Ябык туфракта уңыш начар була*

3) *сөйл.* Һава торышы начар булу сәбәпле, игеннәр уңмаган, азыкка мохтаҗлык зур булган (ел тур.). *Кара да гынай урман, караңгы төн, Ябык еллар, авыр замана. Ахры, кемдер юлдаш таба алмый, Урман буйлап килә, зарлана.* Р.Шәрипов. *«Кара, ничек охшашканбыз!..» – Дип бер көлешсәң иде! Ябык елларның хәлләрен Сорап белешсәң иде.* Р.Рахмани

**2.** *рәв. мәгъ.* Уңышсыз булып, начар хәлдә, ярлы рәвештә. *Россиянең кырларында ул чак агач сука, агач тырмалар. Елның-елы еллар ябык килгән, елның-елы иген уңмаган.* Г.Латыйп. *Җитмәсә, заманасы да ябык килде бит аның! Завод бөлде, эш хакы алу бетте.* М.Маликова

**3.** *хәб. функ.* Игеннәр уңмауны, азыкка мохтаҗлык зур булуны белдерә. *Еллар ябык, Туна буенда да, Идел буенда да тормыш авыр, ни ризыгы, ни күңел кызыккан кием-салымы җитеш түгел.* Т.Әйди. *«Карурман» җырындагы «заманалар авыр, еллар ябык» дигән сүзләр көннән-көн актуальрәк яңгырый...* Р.Фәйзуллин

**ЯБЫК** II *с.* **1.** 1) Ябылган, ачык булмаган; бикле. *Фәтхерахман карт Акъялны, инде өч яше тулып килүгә карамастан, әле һаман ябык абзарда, әнисе янында йөгәнсез-баусыз гына тота иде.* В.Имамов

2) Эшләми торган; эшчәнлек алып барылмый торган. *Каһирәдә танклар, җимерек биналар, ябык мәктәпләр, кибетләр...* Сөембикә. *Авыл саен ябык клублар моңсуланып утыра.* Кызыл таң

3) Өсте ябулы; капкачы булган; өстән һәм ян яктан капланган, ябылган. *Безләрне, өсләре брезентлар белән ябык йөк машиналарына төяп, Павлодардан биш йөз чакрымнар ераклыктагы Биш Карагай районына алып киттеләр.* А.Хәсәнов. *Киен дә чык, тышта сине ябык көймәле арба көтә.* В.Имамов

4) Ачык урыннары, ерыклары, тишекләре булмаган; гәүдәнең күп өлешен яисә билгеле бер урыннарын каплый торган (кием тур.). *Безнең татар халкы өчен хас булган кием – матур итеп яулык бәйләп һәм ябык күлмәк киеп йөрү.* Безнең мирас. *Ябык туфли һәм биек үкчәләр турында онытып торыгыз.* Сабантуй // Ачык булмаган; ябылган (киемнең билгеле бер өлеше тур.). *Аның чүеге Сөмбеләнеке кебек, өстендәге ябык изүле, озын җиңле чуар чәчәкле ситсы күлмәге күрше апасыныкы шикелле, юл тузаны кунмасын өченгә бөркәнгән күгәрчен тамагы төсендәге сатин халаты әнисенекедәй таныш.* К.Кәримов

5) Изүне яба торган; уемы муенга кадәр җиткерелеп, ияк астыннан яки арттан төймәләнә торган (яка тур.). *Рәшиднең өстендә киң итәкле, тар җиңле, ябык якалы кара зәңгәр озын күлмәк иде.* Ә.Еники. *Аның өстендә ябык якалы кыска тужурка, аяк йөзенә үк төшеп торган озын тар чалбар, аягында тәбәнәк үкчәле ботинка иде.* М.Гали

6) Билгеле бер төркем кешеләр өчен генә булган; читләр кабул ителми торган. *Анда үтеп керүе дә җиңел түгел икән – ябык оешма санала!* М.Вәлиев. *Ул бу ябык түгәрәктән чыгу юлын үзе табар.* А.Нәҗми

7) Билгеле бер кешеләргә генә керү рөхсәт ителгән. *Суд утырышының ябык рәвештә үткәрелүе дә очраклы түгел: жандармериянең кара эшен мөмкин кадәр яшерен эшләргә кирәк була.* М.Мәһдиев. *Киров районы судының матбугат сәркатибе Булат Батыршин сүзләренчә, беренче утырыш ябык булачак.* Безнең гәҗит

8) Катнашучыларның саны чикле булган. *Конкурс комиссиясе тәкъдим ителгән эскиз проектларының берсен дә кабул итмәде һәм иң яхшы эскиз проектына ябык бәйге үткәрергә карар кылды.* Сәхнә // Катнашучыларның, авторларның исем-фамилияләре күрсәтелмәгән. *Бу оригиналь әсәр драматургия буенча республика ябык конкурсында бүләкле урыннарның берсен алды.* А.Әхмәдуллин. *Әсәрләр ябык тәртиптә, авторы күрсәтелмичә, бары тик девиз куелып тәкъдим ителә.* Идел

9) *лингв.* Тартык авазга тәмамланган (иҗек тур.). *Шушы юл белән тикшереп карасак, татар телендәге әлеге 9 сузыкның сүзнең башында һәм ахырында да, ачык һәм ябык иҗекләрдә дә һ.б. очракларда да мәгънә аеру өчен хезмәт итә алулары күренә.* Ш.Асылгәрәев

10) мед. Тышкы симптомнары булмаган; эчке. *Нинди туберкулёз: ачык формасы яки ябык формасымы?* Безнең мирас. *Ә ябык формадагы авыру булганда басымны сизмичә мөмкин түгел, чөнки күз алмасы өянәк сыман авыртып ала.* Кызыл таң

11) Читләр белән аралашмый торган, аралашучан булмаган. *Әйтергә кирәк, Казанда уйнаганда, Зиновьев журналистлар өчен иң ябык кешеләрнең берсе булды.* Ватаным Татарстан. *Димәк, алар – характерлары буенча ябык кешеләр?* Татарстан яшьләре

**2.** *хәб. функ.* 1) Бикләнгән; бикле. *Шулай да кибетләрнең күбесе ябык иде, анда-монда төркемләшеп торган, үзара нидер кызып сөйләшкән, сатулашкан кешеләр күренә иде.* Н.Фәттах. *Нигәдер китапханә дә ябык иде.* Н.Гыйматдинова

2) Юк; ачык түгел; өзек; барып, үтеп булмый. *Шашкынлыктан айныгач аңладым: Карамалыга – юл өзелгән, Хәтимәгә – юл ябык!..* И.Юзеев. Шарлык аша Ырымбурга юл ябык. З.Зәйнуллин

3) Бетте, тәмам. *Аннары Солтанов торып басты да: – Партком утырышы ябык, – диде.* Ф.Садриев. *Ишеттегезме сез, җыелыш ябык, дигәнне?!* В.Нуруллин

4) күч. Билгеле бер эшне үтү, башкару мөмкин түгел. *Нәшриятка да юллар ябык.* А.Хәсәнов. *Монда сәүдә өчен бөтенләй юл ябык, ә тегендә, хак булса, салым талап җелегеңне суырмыйлар икән.* В.Имамов

**ЯБЫ́К-КАКЧА** *с.* Чандыр; ит кунмаган. *Апа спектакльдә Искәндәр булып уйнаган ябык-какча гәүдәле Ирек Баһмановка карап алды, аннары, килеп, аның кулыннан тотты да болай диде: – Әйдә үземә кунакка. Хатының явыз сине ачка интектереп, коры сөяккә калдырган лабаса.* Ш.Маннапов. *Карадан киенгән ябык-какча йөзле карт беренче карашка гомерен тауларда үткәргән көтүчене хәтерләтә.* А.Сафин

**ЯБЫКЛЫК** I *и.* Ябык, арык булу сыйфаты. *Ул минем ябыклыктан курыккан икән.* Ф.Яруллин. *Мондый ябыклык, мондый сарылык миңа таныш иде...* Р.Габделхакова

**ЯБЫКЛЫК** II *и.* Бикле, ябык булу хәле. --- *тик шунда татар кибетләренең ябыклыгыннан гына бу көнгә бер үзгәреш килә.* Г.Тукай. *Ни өчен соң кибетләрнең бушлыгы, очсыз-кырыйсыз чиратлары, төрле дәрәҗәдәге ришвәтчелекнең арта башлавы, иҗат ирегенең чикләнү, фикер төрлелеге кысылу, чикләрнең ябыклыгы һәм башка шундый кимчелекләре өчен тәнкыйтьләнгән Совет илен һаман юксыналар?* Шәһри Казан

**ЯБЫКТЫРУ** *ф. йокл. юн. к.* **ябыгу**. *Ә мин сезне ябыктыру өчен башка бер дару да таба алмадым...* Р.Вәлиев. *Әй килен, килен, су тагын да ябыктыра.* Н.Гыйматдинова

**Ябыктыра бару** Торган саен ныграк ябыктыру. *Авыруы аны торган саен ябыктыра бара*

**Ябыктыра төшү** Бераз ябыктыру; тагын да ябыктыру. *Авыр физик эш сине ябыктыра төшкән*

**Ябыктырып бетерү** Бик нык ябыктыру. *Җирәнне ябыктырып бетерделәр, коры сөяккә калып бара – шунысы җанны кыя.* М.Хуҗин. *Ике ай буена көненә берничә мәртәбә сорау ала-ала, һәр сорау алу вакытында бик нык кыйнап, тәмам хәлсезләндереп, ябыктырып бетергәннән соң, ниһаять, Мичуринны төрмәдән чыгаралар.* Р.Мостафин

**ЯБЫЛМАЛЫ** *с.* Ябыла торган, каплана, томалана торган. *Шулвакыт киң мәрмәр баскыч төбенә як-ягына фонарьлар куелган, бик яхшы ябылмалы җиңел тарантаска җигелгән пар ат килеп җитте.* М.Хәсәнов. *Ул ян стенага беркетелгән ябылмалы шкафтан ике стакан алып, аларга чүлмәктән шаулап күбекләнеп торган саргылт сыекча агызды.* Г.Тавлин

**ЯБЫЛУ** *ф.* 1) *кайт. юн. к.* **ябу** I. *Кабина ишеге шапылдап ябылды, һәм алар кисәк кенә кузгалып киттеләр.* Н.Фәттах. *Әнигә икәүләп кул изәгәч, лифт ишеге янә теләр-теләмәс, озаклап кына ябылды.* А.Әхмәтгалиева

2) *төш. юн. к.* **ябу** I. *Пләтән төрмәсендә күпмедер ябылып ятканнан соң, аны, каты авырып китүе сәбәпле, төрмә шифаханәсенә күчерәләр.* Р.Мостафин. *Хәдичә азга гына, әйтергәмеюкмы дигәндәй уйлангандай булды да Кавины сискәндереп җибәрде: – Утыз сигезенче елны алты айга якын мин НКВД подвалларында, төрмәсендә ябылып яттым.* З.Зәйнуллин

3) Йомылу. *Ә төн җиткәч, суынгач, чәчәк ябылган – зинданга әверелгән, кояш чыкканчы, нечкәбил тоткын җырын җырларга мәҗбүр*. Ә.Зарипов

4) Бөтәшү, төзәлү. *Яра ябылганга карап, авыртуы, әрнүе кимегәндерме, юктырмы – анысын инде үзе генә беләдер.* Сөембикә. *Ләкин әле тагын ике ел янбашындагы яра ябылмый.* Кызыл таң

5) *күч.* Кешеләр белән ачылып сөйләшүдән, аралашудан туктау. *Элек тә бик болагай хатын түгел иде, хәзер бөтенләй ябылды.* Р.Батулла. *Ни ачык кеше шул мизгелдә көзгә күренеп үзүзенә ябылды.* Д.Гыйсметдин

◊ **Ябылып яту** 1) Нинди дер ашыгыч эшләр, мәшәкатьләр яки башка сәбәпләр аркасында өйдән беркая чыга, беркая бара алмау. *Һәммә кеше йөри дә йөри, мин генә тик ябылып ятам, миңа ни бәйрәм юк, ни җомга юк.* Г.Камал. *Һичкайда чыгу юк миңа, мин бу өйдә ябылып ятам, Бераз гына булса да хәл җыймыйм эштән ичмасам.* И.Хәйруллин; 2) Үсмәү, алга бармау, яңалыкка каршы булу, дөнья белән кызыксынмау. *Кешеләргә, күбрәк укыгыз, күбрәк сәяхәтләр ясагыз, үзара аралашыгыз, үзегезгә генә ябылып ятмагыз, дияр идем.* Яңарыш

**Ябыла бару** Аз-азлап, акрынлап ябылу. *Улы турында әйтелгән һәрбер җылы сүз ана йөрәгендәге ярага шифалы яфрак булып ябыла барды.* Г.Галиева. *Милли мәктәпләр ябыла бара, татар китапларын басу нык кими.* М.Вәлиев

**Ябыла башлау** Ябылуга таба бару; ябылырга тотыну. *Җил минем уйларымны иртеп алып китә, керфекләрем авыраеп ябыла башлый, башым күкрәгемә салына, кинәт үзем гырлаганны үзем ишетеп, сискәнеп, башымны күтәрәм.* А.Гыйләҗев. *Ул әле бер уйга килергә дә өлгермәде, лепелдәп ябыла башлаган ишекне каерып, автобуска кереп тә китте.* Л.Ихсанова

**Ябыла килү** Күптәннән бирле һаман ябылу. --- *кай тирәләрдә бездән «качып йөри» икән ул «яулап алынган хөррият», тоташтан ябыла килгән татар мәктәпләре, гуманитар я педагогика институтлары, юкка чыгарылган милли факультетлар бусагасында яшь агызып ятамы ---?* Т.Галиуллин. *Татар мәктәпләре күпләп-күпләп ябыла килгән, «татар теле озакламый бетәчәк» дигән фикер югары оешмаларда һәм халыкта да һаман ныгый килгән чорда!* М.Вәлиев

**Ябыла тору** Даими, әледән-әле ябылу. *Мәктәпләр дә ябыла тора.* И.Фәйзрахманов. *Базарның сәүдә урыннары берәм-берәм ябыла тора, сәүдәгәрләр малларын башка җиргә күчерә башлыйлар.* Шәһри Казан

**Ябыла төшү** Бераз ябылу. *Нечкә сүзне әйткәндә, ияк ябыла төшеп, тел алгарак килә.* Г.Алпаров. *Һаман да бер үк төрле сораулар туйдырганга, мин ябыла төштем.* Шәһри Казан

**Ябылып алу** Билгеле вакытка ябылу. *Үз бүлмәсендә ябылып алган Газизчик тыныч кына бер көйне скрипкасында уйнап җибәрер дип, берсе дә көтмәгән иде.* Ф.Яхин

**Ябылып бетү** Бөтенләй ябылу; барысы да ябылу. *Ябылып бетмәгән яраңа тагын тоз салсам, кичер, халкым.* А.Хәсәнов. *Шул вакыт, борыны белән ябылып бетмәгән абзар ишегенән ачып, бакча якка Сөнгатьнең дуңгызы килеп чыкты.* Аманулла

**Ябылып җитү** Тулысынча ябылу, тиешенчә ябылу. *Ут яндыруга, өстәлдәге тәмәке төпчеге, арткы яктан чыга торган ишекнең ябылып җитмәве Вафаның шиген арттыра.* А.Алиш. *Икенчесе – пыяла күзенең кабагы – ябылып җитми.* Г.Мөхәммәтшин

**Ябылып калу** Нindидер сәбәптән ябылу; ябылырга өлгерү. *Минем белән бергә тагын дүрт кеше ябылып калды.* Г.Гыйльманов. *Вера артыннан җилкапка ябылып калганда, авыл татлы йокыда иде әле.* З.Мурсиев

**Ябылып килү** Ябыла башлау, бераз ябылу; ябылуга таба бару. *Ул шул сүз берлә Вәли мәхдүмнең ябылып килә торган ярасын тагы уятты.* Г.Исхакый. *Янәшәдә генә инде түбәсе ябылып килгән соры төстәге таш терлек абзары, берникә исе китмәгәндәй, югарыга ашкынып утыра иде.* А.Вергазов

**Ябылып китү** Кисәк ябылу; ниндидер сәбәпләр аркасында, нәрсәдер тәэсирендә ябылу. *Егет балта белән чөйнең очына бер генә бәргән икән, чөй атылып та киткән, агач ярыгы шап итеп ябылып китеп, Шүрәленең бармагын да кысып алган.* Әкият

**Ябылып кую** Ябылган хәлгә килү. *Аңа [мәдрәсәгә] бөтенләй ябылып кую куркынычы да яный әле.* С.Поварисов. *Әле генә без казыган кабер үзлегеннән ябылып куйды, җитмәсә, кара җир яшел чирәмгә әйләнде, чәчкәләр үсеп утыра, ботакларда кошлар сайрый, диләр.* З.Мурсиев

**Ябылып тору** Даими ябылу; вакытлыча ябылу. *Ул таза-сау, ябылып торудан бераз төсе генә качкан иде.* М.Маликова. *Мәктәпләрдә татарча укытылды, клублар ябылып тормады, театрлар уйныйлар иде.* Д.Каюмова

**Ябылып яту** *сөйл. к.* **ябылып тору**. *Син хөҗрәңдә ябылып ятасың икән, Абдул.* Г.Әпсәләмов

**ЯБЫЛУЧЫ** *и.* Кулга алынган, төрмәгә ябылган кеше. *Тәүлек ярымнан (ябылучылар егерме-утызлап кеше җыелган иде) кайсыдыр бер шәһәргә китереп төшерделәр.* Ә.Баян. *Ябылучылар арасында гаиләсендә фәкать кызлар гына булган Гайнулла агай да була.* Ф.Гарипова

**ЯБЫЛЫ́Р-ЯБЫЛМАС** *рәв.* Ярты-лаш ябылган яки ябылып бетмәгән килеш. *Хөрми авызын ачты, башы салынып төште, ияге кинәт салынды, бер күзе ачык, бер күзе ябылыр-ябылмас калды.* Р.Батулла. *Капка да элеккеге, бер як баганасы янтайганга, ябылыр-ябылмас тора.* Г.Якупова

**ЯБЫНГЫЧ** *и. сөйл.* 1) Өскә ябына торган юрган, одеял, плед, җәймә һ.б. нәрсәләр. *Өс киемнәрен салып бер читкә куйды, иске ябынгыч астына кереп ятты да шундук йокыга китте.* Н.Фәттах. *Бер ябынгычлы бер ятакта ике кеше йоклаган.* Ә.Мушинский

2) *сир.* Ябынча, бөркәнчек. *Монда ул аны затлы кием, кыйммәтле ябынгыч бөркәнгән яшь кенә кыз рәвешендә сурәтли.* Т.Әйди

**ЯБЫНУ** *ф.* 1) Өскә нәрсә дә булса ябу, каплау. *– Берни дә әйтмим, – диде Гөлфинур һәм вак чәчәкле тышлык белән тышланган йон одеялны өскә тартып, башыннан ук ябынып ятты.* А.Вергазов. *Шуннан соң гына тынычланып, өстенә мал карарга кия торган халатын ябынды да чыгып китте.* Г.Гыйльманов

2) Нәрсәне дә булса башка бөркәнү яки бәйләү. *Әби, төенчегеннән алып, аякларына юка гына, өр-яңа ап-ак йон оекбашлар киде, яулыгын ябынды да намазлыкка басты.* З.Зәйнуллин. *Алсу күлмәгенең кыска җиңнәрен сыпыра-сыпыра, олы шакмаклы кара шәлен ябынды.* Ф.Җамалетдинова

3) *күч. шигъ.* Нәрсә белән дә булса каплану, өртелү (табигать күренешләре тур.). *Тирә-юнь яшел юрган ябына, юкә ябалдашларында сандугачлар сайрый, күке кычкыра.* К.Хисаметдинова

**Ябына башлау** Ябынырга тотыну, ябынырга керешү. *Тәннәрендәге ул йон гына аларны салкыннардан, төрле табигать көйсезлекләреннән саклый алмагач, борынгы бабаларыбыз үзләренә азыкка үтергән җанварларның тиреләрен салдырып, өсләренә ябына башлаганнар.* Г.Тавлин. *Агачлар, моңаеп, яфракларын коя башладылар, җир үзенең сарылы-яшелле мамыктай йомшак юрганын ябына башлады.* Көмеш кыңгырау

**Ябына төшү** Бераз ябыну; тагын да ябыну. *Акыртын гына торып утырды, бөтен тәненнән, бик кызулап үтеп бара торган карлыгач очуы кебек, тәнен чемердәтеп, бер суыклык, бер чиркану узды, юрганын ябына төшеп, янындагы шырпысын кабызып идәнгә басты.* Г.Исхакый

**Ябынып алу** Берникадәр ябыну. *Бакчадагы шул сары, кызыл төсле яфракларны ябынып алгач, җирдә икенче төрле тормыш башланган кебек.* Ф.Сафин

**Ябынып җибәрү** Тиз генә ябыну. *Менә шул кофтаны ябынып җибәр, җылынып китәрсең.* Сөембикә

**Ябынып карау** Сынау өчен ябыну. *Карчыкның карт күзләренә нур кереп китте, күңеленә дулкын йөгерде, гомерендә күрмәгән җылы мамык шәлне, балалар кебек шатланып, шунда ук ябынып карады.* Г.Ибраһимов

**Ябынып кую** Ябынган хәлгә китерү; алдан ябыну. *Хәтта инде, миннән яхшырак качар өчен булырга кирәк, башына шәл дә ябынып куйган.* Г.Рәхим. *Әйтерсең сыер фермасында чәчкә бәйрәме: кызлар әниләренең кунакка гына бәйли торган яулыкларын фермага эшкә ябынып киләләр, кайберсе сандык төбеннән чәлдереп алып килә дә солдатлар күренгәч кенә ябынып куя.* З.Кадыйрова

**Ябынып тору** Әле, хәзер ябыну; вакытлыча ябыну. *Тукталышта автобус көтеп, шул «чапан»ны ябынып тордым.* Шәһри Казан

**ЯБЫНЧА** *и.* 1) Хатын-кызлар йөз яшерү өчен ябынып йөри торган махсус бөркәнчек. *Ул карады миңа бары бер генә кат, Шуннан башын бөкте, бакмады. Мин карадым, ә ул йөзкәйләрен Ябынчасы белән каплады.* Һ.Такташ

2) Гомумән кием өстеннән бөркәнеп йөри торган җиңсез кием. *Кам Ана мөгезле тастарын, ябынча күк тәкә тиресен салып куйды, йокы бүлмәсенә кереп, ятакка ауды.* Л.Зөлкарнәй. *Таң атар-атмаста алар күрде: барасы юл өстендә кара ябынча бөркәнгән бер җайдак тора.* Р.Батулла

3) Фата. *Күзләр аша күңелгә үтеп уелганы: кием шкафының өстәге тоткасына эленгән ап-ак туй күлмәге, чәчәкле калфакка беркетелгән өрфия ябынча һәм идәндәге ак туфлилар.* К.Булатова

4) Мантия. *Айдар Фатих улы аңа хөкемдарның иң мөһим һәм даими төп билгесе булган мантия (ябынча) тапшырды.* Идел

5) *зоол.* Кайбер умырткасыз хайваннарның тәнен каплаган тире катлавы. *Моллюскларның ябынчасы*

**ЯБЫНЧЫК** *и. диал. к.* **ябынча**. *Соңлап чыгуымның үз рәхәте булды: ап-ак озын күлмәк тектердем, ак ябынчык бөркәндем, ак туфлилар кидем, балдаклар алыштык.* К.Тимбикова. *Ястыгын, мендәрен, астагы камыш чыптаны, ябынчыкларын – бөтенесен бер төргәккә төреп, читкәрәк алып куйды һәм йөгереп кенә тимер көрәк алып килде.* Н.Фәттах

**ЯБЫРЫЛМА** *и.* 1) Таулы җирләрдә җил, яңгыр, кар сәбәпле кинәт кузгалып, актарылып килә, өстән ишелә торган кар, ком һ.б.ш. ташкыны. *Ханның бабасы Елбаздук белән үги анасы Баялун тауларда кар ташкыны – ябырылма астында калып һәлак булганнар.* Казан утлары

2) күч. Бер якка күпләп хәрәкәтләнә торган зур төркем; ташкын. *Гаскәр ябырылмасы*

**ЯБЫРЫЛУ** *ф.* 1) Ашыгып, каударланып, барысы бергә кинәт бер үк юнәлешкә, бер үк нәрсәгә ташлану. *Халык, ташкын булып, ишекләргә ябырылды.* В.Нуруллин. *– Ахырзаман килде, ахырзаман! – дип кычкырып, яллы сакчылар, берсен берсе изә-сыта, тимер капка бигенә ябырылды...* В.Имамов

2) Нәрсәне дә булса күп булып, кинәттән каплап алу; сарылу, уратып алу. *Бу халык хисапсыз иде, алар, еракտан каралып яткан нарат урманнарыннан алып Идел белән кала арасында булган бөтен болынны, шикәргә ябырылган кара чебен кеби сарып алганнар иде.* Гали Рәхим. *Инде җәйнең озын көне сүрелеп, ишегалдындагы баганада лампа кабызырлык караңгы иңгәч, хуҗа кеше түзмәде, черки ябырылган муенын каплардай кием эзләп өйгә кереп киткән җиреннән юк булды.* К.Кәримов

3) Комарлык яки комагайлык белән берәр эшкә, шөгыльгә тотыну. *Республика җитәкчеләребезнең күбесе, ни сәбәптәндер, спортка ябырылдылар, ә рухи дөньябыз, мәдәни һәм тарихи байлыкларыбыз икенче планга күчте.* Р.Вәлиев

4) Комсызланып һәртөрле ризыкка, ашау-эчү әйберләренә ябышу, ташлану. *Бала-чага, яшүсмерләр шау-шу килеп талаша-талаша боткага ябырылдылар һәм бер бөртеген дә калдырмыйча ашап бетерделәр.* М.Галәү. *Кунаклар исә кайтып төшүләре белән сусыл җимешләргә ябырылдылар.* К.Тәхау

5) Берәр процесс, вакыйга һ.б.ш.ның көтмәгәндә, берьюлы һәм кинәт булуы турында. *Мең елларга киткән тарихыннан – Борынгыдан килә Казаным, Тирән эзен салып катламнарга Ябырылган бәла-казаның.* Ф.Тарханова. *Кинәт ябырылган бәла алдында каушап калу да – була торган хәл.* Кызыл таң

6) *күч.* Кинәттән бик күп булып һөҗүмгә ташлану. *Акгвардиячеләр һәм ак чехлар Көнчыгыш фронтка ябырылдылар.* М.Хәсәнов. *Исән калганнар, аркага арка куеп, атларының койрыгын койрыкка борып, җан ачысы илә акырып, бихисап күп дошман гаскәренә ябырылдылар.* Р.Батулла

7) *күч.* Кемгә дә булса берничә кеше кинәттән күп итеп сораулар бирү яки, канәгатьсезлек белдереп, тәнкыйть сүзләре яудыра башлау. *– Бала табамы? – дип, сораулар белән ябырылдылар.* Г.Кутуй. *Чираттагы бер педсовет утырышында укытучылар Зайцевка ябырылдылар.* В.Имамов

8) *күч.* Берьюлы күп булып килү, туу, төшү (уй, фикер, хис тур.). *Ул арада Зиннәтнең җилбәзәк күңеленә тагын авыр уйлар ябырылды...* Г.Гыйльманов. *Шулай да торып китәсе килми, җанга көз суыклыгы гына түгел, хәтер төпкелендәге авыр уйлар да ябырылып маташа иде.* Сөембикә

◊ **Ябырылып төшү** Берьюлы күп булып килү; каударланып, ашыгып, берьюлы күп булып нәрсәгә дә булса ташлану. *Бөтен бер ил өстенә кинәт ябырылып төшкән авырлыклар, канлы фаҗигалар да, асылда, шуңардан башланды.* Ә.Еники. *Нигә берәү дә аның хәлен сорашмый, аның чал башына кинәт ябырылып төшкән хәсрәтен бүлешергә ашыкмый?..* А.Гыйләҗев. **Ябырылып яту** Нәрсәгә дә булса ябышкандай, кузгалмыйча тору. *Әмма мондый китапларга ябырылып ятучылар без үзебез түгелме соң?!* Р.Зарипов. *Менә шулай фәннәргә ябырылып ятучы студентларыбыз гаилә тормышыннан читләшә башлады.* Безнең гәҗит

**Ябырыла башлау** Ябырылырга тотыну. *Көннәрнең берендә азгын казанлылар Сафагәрәй ханга каршы кузгалып, өстенә ябырыла башладылар.* Һ.Атласи. *Ә Хәдичә өстенә бер-бер артлы бәхетсезлекләр ябырыла башлады.* М.Хәсәнов

**Ябырыла тору** Берөзлексез ябырылу; һәрвакыт, гел ябырылу. *Чөеп ыргыта торабыз, өскә ябырыла торалар.* Ф.Яруллин. *Тик бу – халыкны туктатып калмады, ишектән кергән берсе шул буфетка ябырыла торды.* Безнең гәҗит

**Ябырыла төшү** Тагын да ныграк ябырылу. *Халык ябырыла төште*

**Ябырылып алу** Тиз генә ябырылу. *Беркөнне теге кыз өч балаклы ыштан теккән дә, бу абыстайны талчукка сатарга чыгарган, талчукның бөтен халкы ябырылып алып, бөтен базарны күтәргәннәр.* Г.Исхакый

**Ябырылып тору** Һәрвакыт, гел ябырылу; әле, хәзер ябырылу. *Машиналарының гомерен шул рәвешчә азмы-күпме озайтырга тырышып һәм сезонлы эшкә ябырылып торучы урыс, татар, мари крестьяннарын алдаштырып, ул үзенә акча туплый һәм шул акчага соңыннан чит илдән кыйммәтле, ләкин һәйбәт машиналар алдыртмакчы була иде.* М.Галәү. --- *тәхет өчен Күчемнең бабасын үтергән тайбугачыларны да, тайбугачыларны үтергән шәйбәниләрне дә, Себер өстенә даими рәвештә үлем явы белән ябырылып торган кыргызкайсакларны, казахларны да күздә тота карт чичән, чөнки алар барысы да төрки-мөселманнар бит* ---. Ф.Бәйрәмова

**Ябырылып яту** *сөйл. к.* **ябырылып тору**. *– Минекеләр китмиләр, үлән булса, ябырылып яталар, – дип, атларын озын гына тышаулап җибәрде.* Г.Ибраһимов

**ЯБЫРЫЛЫШУ** *ф. урт. юн. к* **ябырылу**. *«Кырылыш бар», – дип җилләр, барып, төрле якка зарлар салгач, каргакозгын, кан өстенә ябырылышып, каркылдашып, әйтерсең лә үләләрдән көлә-көлә шаркылдашып, көбәкүзләр кигән күкрәкләр өстенә утырдылар; үлем калдырган байлыкны бүлешергә тотындылар.* Г.Рәхим. *Әнә шул мәет җаннар, төнге ярканатлар кебек, безнең изге имәнебезгә дә ябырылышканнар, аны фашист билгеләре белән тутырганнар, имеш.* Т.Нурмөхәммәтов

**ЯБЫШКАК** *с.* **1.** 1) Бик ябыша торган, ябышучан. *Аның каравы кичке чәйгә «борын» саен берәр ябышкак карамель эләгә.* А.Тимергалин. *Кышын каз мамыгыдай ак кар белән капландылар, язын нарат сагызыдай ябышкак сазга чумдырдылар.* Ф.Җамалетдинова

2) *күч.* Бәйләнчек, бәйләнүчән. *Аның, билгеле, бу ябышкак карчыкны селтәп ташлыйсы килде, ләкин аның йөзенә күтәрелеп карагач, аның чандыр йөзендәге, эчкә баткан нурсыз күзләрендәге коточкыч кайгы, әрнү күреп, тетрәнеп китте.* Н.Фәттах. *Бәхтияр шәкерт ябышкак кунак кыздан арына алмый.* С.Сабиров

3) *күч.* Бер дә күңелдән, баштан чыкмый торган. *Мунча сагызы төсле ябышкак уйларын куарга тырышты Сәет.* Т.Галиуллин. --- *тик ни өчендер ул әрсез һәм ябышкак хисләреннән бөтенләй үк котыла алмый, уйлары бүтән хасиятләр белән яшәгәндә дә, кайдадыр якында гына, әлеге нәрсәнең тынгысызланып хәрәкәтләнгәне күзен чекерәйтеп белгертеп тора.* А.Вергазов

**2.** *и. мәгъ.* 1) Ябыша торган әйбер. *Зәкәрия күземнән ябышкакны кубарып алды.* Бу тормышта ниләр бар?

2) *күч.* Бәйләнчек кеше. *Аннары мин үзем дә аңа артык сырышмадым, кыенсындым, «ябышкак» булудан, әрсез булып күренүдән сакландым.* Л.Шагыйрьҗан. *Минем сүземә ышанмасаң, кич үзең күрерсең: ирең Сариягә борылып та карамаячак. Сиңа ябышкак булып ябышачак.* Ш.Җиһангирова

**ЯБЫШКА́К БАЛЫК** *и. зоол.* Ябышкак балыклар семьялыгыннан барлык океаннарның җылы суларында тереклек итүче, башында ябышу органы булган куе соры, коңгырт төстәге балык; русчасы: **рыба-прилипала**. *Кайбер очракларда, акула белән ябышкак балык арасындагы кебек, бәйләнеш берсе өчен генә файдалы була: ябышкак балык акуланы хәрәкәтләндерү чарасы итеп файдалана.* Биология

**ЯБЫШКАКЛАНУ** *ф. сөйл.* 1) Ябышкакка әйләнү. *Боламык ябышкакланган*

2) Бәйләнчекләнү, тагылу, бәйләнчеккә әйләнү. *Матур кызлар күрсә, ябышкаклана ул шулай.* Идел

**Ябышкаклана бару** Торган саен күбрәк ябышкаклану. *Яфраклар ябышкаклана бара*

**Ябышкакланып тору** Сөйләү моментында яки гомумән ябышкак булу. *Ә менә берничә көн дәвамында яткан ит кисәге шәлперәйгән кебек күренә, кул белән тотканнан соң ябышкакланып тора.* Заман сулышы

**ЯБЫШКАКЛЫК** *и.* Ябыштыру үзлегенә ия булу. *Аның картерын ачып, үлчәгеч таяк белән майны учына алды да күрсәтә-күрсәтә: – Кара, әнә төсе дә үзгәргән, бармагыңа буяп тикшер, ябышкаклыгы беткән, сизәсеңме? – диде.* Х.Камалов

**ЯБЫШКА́К ҮЛӘН** *и. бот. сөйл. к.* **сырлан**. *Ябышкак үлән чәнечкеле чикләвек сыман җимеш бирә.* Ботаника

**ЯБЫШТЫРГЫЧ** *и.* **1.** 1) *сөйл.* Пластырь. *Ябыштыргычны куптарып карадылар, кендек янә астан өскә таба йөри башлады, хатын тиз генә аны киредән ябыштырып куйды.* З.Хөснияр

2) Кәгазьдән яисә башка шундый юка, җиңел материалдан ясалган һәм бер ягына төрле рәсемнәр, символлар төшерелгән, икенче ягы ябышу үзлегенә ия булган нәрсә; *русчасы:* **наклейка**. *Әгәр сатучы татарча белә икән, сату аппаратына махсус ябыштыргыч беркетәләр.* Ватаным Татарстан. *Айфонында – «Парклар һәм скверлар елы» эмблемасы төшерелгән ябыштыргыч.* Шәһри Казан

3) Аяк һәм өс киемнәрендә һ.б.ш. әйберләрдә төрле өлешләрне, якларны бер-берсенә беркетү максатларында кулланыла торган, кыллары булган материалдан һәм йөнтәс өсле тукыма кисәгеннән гыйбарәт җайланма; *русчасы:* **липучка**. *Баланың әнисе ябыштыргыч белән куела торган коткару түгәрәген кигертеп, бер минутка гына калдырып китә.* Мәйдан

4) *сөйл.* Эретеп ябыштыргыч; *русчасы:* **сварка**. *Тимер-томырны ябыштыру хаҗәтең белән аны эзләп килсәң, көне буе янында утыртып, кичкә беркие җирдән ябыштыргыч белән төртеп бирә инде анысы, рәхмәт төшкере, йомышлыны алай бер дә кире какмый.* Ф.Яхин

**2.** *с. мәгъ.* Ябыштыра торган; ябышу-ябыштыру үзлегенә ия булган. *Булса, фоторәсемгә төшереп, ябыштыргыч тасмага күчерерсез.* М.Насыйбуллин. *Башта катыргылардан сылап каркас ясала да, ябыштыргыч алман кәгазе белән тышлана.* Безнең гәҗит

**ЯБЫШТЫРГЫ́Ч ТАСМА** *и.* 1) *сөйл.* Пластырь. *Тик һәр мунча саен ябыштыргыч тасманы алыштырып кына торасы.* З.Хөснияр

2) Ремонт вакытында, берәр нәрсә ясаганда яки көнкүрештә кулланыла торган, ябыштыру үзлегенә ия лента, скотч; *русчасы:* **клейкая лента**. *Шулай ук ул линолеум өчен җилем, ябыштыргыч тасма, гидроизоляция өчен материаллар җитештерүдә дә кулланыла.* Төзү материаллары

**ЯБЫШТЫРМА** *и.* **1.** *махс.* Китап эченә ябыштырып куелган өстәмә бит яки рәсем. *Китап ябыштырмасы*

**2.** *с. мәгъ. сөйл.* Ябыштырылган, ябыштырып куела торган. *Өстән кушу буенча, борынгы классик стильдә, шактый купшы итеп проектланган йортны «гадиләштерәләр»: коринф стилендә бизәлгән колонналарны вәхшиләрчә җимерәләр, гипстан ясалган матур-матур ябыштырма бизәкләрне ватып чүплеккә ташлыйлар, әзер таш вазаларны зур чүкеч белән чәлпәрәмә китерәләр.* Р.Мостафин

**ЯБЫШТЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **ябышу**. *Балчыгыгыз бигрәк үзле икән, туфлины ябыштырып кала, ди.* Н.Хәсәнов. *Көннәрнең эсселеге хәтта чиста ак күлмәкне дә тәнгә ябыштыра, Казан тузанының исе тамакка утыра иде.* Ф.Яхин

2) Ябышу үзлегенә ия нәрсә кулланып яисә эретеп, чүкеп, әйберләрне берберенә ялгау; үзара беркетү. *Ике тәүлек тоташтан бишенче йортның подвалында торбалар ябыштырам.* А.Гыйләҗев // Төрле кисәкләрдән, әйберләрдән яңа бер нәрсә әзерләү, ясау. *Аннары бик тырышып, линейка, циркуль белән сызып, җилем белән ябыштырып, калькадан очлы калфак ясады.* М.Маликова

3) Төрле ябыштыргычлар ярдәмендә нинди дә булса өслеккә, җирлеккә башка бер әйберне беркетеп, берләштереп, бер итеп кую. *Мин марка ябыштырырга онытуымны хатны почта тартмасына салгач кына исемә төшердем.* Т.Әйди. *Мин күзем белән идән-түшәмне, стеналарны айкап чыктым – ап-ак обой ябыштырылган түшәм уртасында тырпаеп торган тимер боҗраны гына мәзәксенеп, сораулы караш белән дүрәтәемә төбәлдем.* А.Әхмәтгалиева. *Документка фоторәсем ябыштыру*

4) Берәр урынга дәвалау, каплау һ.б.ш. максат белән ябыша торган әйбер беркетү. *Гәүһәр апа белән Сәрия Әбүзәргә беренче ярдәм күрсәттеләр: маңгаена йод сөртеп бәйләделәр, колак артына пластырь ябыштырдылар.* А.Тимергалин. *Пирамидага ике катлы скотч ябыштырып яки җилем сызып чыгабыз.* Сөембикә

5) Гомумән нәрсәне дә булса башка бер әйбергә төшмәслек итеп беркетү, кую. *Шул кымшанган арада, Нәсимәнең яңа гына ябыштырып киткән марлялары да кубып төшкәли.* Ф.Яруллин. *Үги ана яфрагы ябыштырып, аның да канын туктатты.* В.Нуруллин. *Кояш ашамасын өчен борынына кәгазь ябыштырган, бейсболка маңгайчасы астыннан күтәрелеп караганда, почык борыны күккә чөелә, әллә масая инде...* А.Тимергалин

6) Йөз-кыяфәтне үзгәртү яисә тагын да матурайту максаты белән, вакытлыча беркетү, булганына өстәү, ялгау (сакал-

мыек, каш-керфек, чәч һ.б.ш. тур.). *Бу кашларыңны ябыштыргансың дип торам.* А.Хәмзин. *Батырҗан дәрвиш булып киенгән: сакал-мыек ябыштырган, чапан-чалма кигән.* А.Гадел

7) Җилем яисә башка ябыштыргыч ярдәмендә нәрсәне дә булса ачылмаслык итү, тишеген томалау. *Конвертын тәкерек белән ябыштырып, өстенә китап бастырып куйгач, берара моңсуланып уйланып утырды.* Ф.Җамалетдинова. *Авызын скотч белән ябыштырып, аркасына үтүк белән басканнар.* З.Мәхмүди. *Тәрәзә ярыкларын ябыштыралар.* К.Кәримов

8) Ватылган, кителгән әйбернең кисәкләрен, өлешләрен җилем яки башка шундый ябыштыргыч әйберләр ярдәмендә беркетеп кую, төзәтү. *Бер ватылган чүлмәкне ябыштыра алганнары юк әле.* З.Хәким. *Самавырлар ябыштырып, тырмаларының сынган тешләрен утыртты, атларын дагалап җибәрде, кубыз, курай эшләп бирде, әмма сихергә кагылмады.* Г.Гыйльманов

9) Вакуум һ.б.ш. белән беркетү; орындырып кую; бик нык якын китерү. *Автоимгечләрне һәр сыер имчәгенә ябыштыра.* Р.Батулла. *Әнизәр, бер кочак кәгазь күтәреп лифттан чыгып килгәндә, колагына телефонын «ябыштырган» берәү белән бәрелеште.* Г.Гыйльманов

10) Бер-берсенә кушу, бәйләү (сүз, җөмлә, фикер тур.). *Сүзнең мондый төскә керүе мәҗлесне җиңел сулатып, авызы ачык калган агай-энегә газиз җаннарын кире кайтарды, Алабай исә, җөмләләрен чак ябыштырып, сәйләндәй итәргә тырышып тезеп тә алып китте: – Мәнә бит, карендәш!* Ф.Яхин

11) *күч. гади с.* Җәза, шелтә бирү; чәпәү. *Судка тарту гына түгел, бер өч ел ябыштырулары бик мөмкин.* Ш.Камал. *Дуслар бит «өшкерәләр»: «Хатаңны кабатлама!» – дип, Шелтә ябыштыралар...* С.Рәхмәтулла

12) *күч.* Каты итеп, ачу белән әйтү; сылау. *Рәсим ачулы сүзләрен тутырып, тәмам борычлап җавапламакчы булган иде дә, бригадир аңа ябыштырып та өлгерде: – Күперенмә, күркә булырсың!* Ф.Яхин

13) *күч.* Кемгә дә булса сылтау, аңа кагылышлы итү, аның өстенә аудару. *Шушы шикләрнең берсен дә ябыштыра алмыйсың Ирбулатка.* Ф.Баттал. *Унсигезенче елда Кырым комиссарларын үтерү вакыйгасы турында ишетеп беләсең. Әнә шул эшне ябыштырырга исәпләре.* Р.Мөхәммәдиев

14) *күч. гади с.* Бирү, кушу (исем, кушамат тур.). *Чепек күзле чуваш Степанга җеназа вакытында буталып йөргәне өчен ябыштырыла «мәет козгыны» дигән атама.* С.Поварисов. *Бигрәк ямьсез кушамат инде, иеме? Гел уйламаганда ябыштырдылар миңа аны.* А.Гыймадиев

15) *күч. гади с.* Тагу (исем, ярлык һ.б.ш. тур.). *Дөрес, музейга милләтчелек ярлыгы ябыштырырга сылтау табылмый, әмма, милли ихтыяҗларын канәгатьләндерүне таләп итеп, Кишинёвка һәм Мәскәүгә гагаузларның хатлар яудыруы артуын башкача ничек аңлатасың?* Т.Әйди. *1990 елга чаклы, әдипнең исеме, әдәби мирасы туган халкына яңадан кайтканчыга тикле, 1917 елга кадәрге Г.Исхакый буржуаз-милләтче язучы дип йөртелгән шикелле, аның эмиграция чоры эшчәнлегенә дә төрле сәяси ярлыклар ябыштырылды, ә Икенче бөтендөнья сугышы елларындагы сәяси мәсләге, тоткан юлы хакында төрле имеш-мимешләр йөрде.* М.Хәсәнов // Берәү турында дөреслеккә туры килмәгән фикер тудыру, анда булмаган сыйфатны бар дип күрсәтү. *Мәнә ул сәяхәтнамәдә төркиләргә ябыштырылган ялган юллар.* М.Хәбибуллин. *Шәмгунның башкалар аңа ябыштырып сөйләгән «усаллыгы» юклыгын Гөлнара аңларга өлгерде.* Ф.Яхин

16) *күч. сөйл.* Кыстыру, ялгау, дәвам итү, кирәкле сүзне кушып җибәрү. *Егетләрнең берсе [бу хәбәрне] сүз арасында килеп чыккан бер әңгәмәгә ябыштырып әйтте.* Ш.Камал

17) *күч.* Соңыннан кушу; табигый булмаганча, ясалма рәвештә берләштерү. *Язылган әсәргә, халыкны күңелләндерү өчен, аерым җыр, бию картиналары кертеп, музыка язып ябыштыру әсәрнең дә, музыканың да әһәмиятен генә югалталар.* М.Җәлил

18) *күч.* Ияртү, алу, үзендә булдыру. *Сез моннан кайтып киткәндә анализларыгыз бик яхшы иде, ә хәзер сез үзегезгә тагын бер чир ябыштыргансыз.* З.Кадыйрова

19) *күч.* Үзенә тарту, җәлеп итү; якын, үз иттерү, җылы хисләр уяту. *Бер йөрәкне бер йөрәккә ябыштыра торган кич...* Т.Миңнуллин. *Чебенне – бал, каракны мал ябыштыра.* Х.Бәдигый. *Колагында һаман әле яңгырап торган бала тавышы аны әлеге таш йортка ябыштырып-беркетеп куйган иде.* Г.Гыйльманов // Үзеңә бәйләп кую; яраттыру. *Хәзерге егетләрне көчләп үзеңә ябыштырмасаң, алар сакалы агарганда да өйләнми!* Н.Гыйматдинова. *Аптырыйм: нинди көч вә сихер берлән Ябыштырдың садә җанымны үзеңә.* Ш.Җиһангирова

20) *күч. гади с.* Сугу, сугып җибәрү; кундыру. *Егеткә бик каты ябыштырдылар ---.* Кызыл таң

◊ **Ябыштырып алу** *этн.* Кызны, ата-анасы ризалыгыннан башка, яшерен никах укытып, хатынлыкка алу. *Ата-анасыннан ризалык сорамыйча, кызны ябыштырып алдың бит.* Г.Әпсәләмов. *Кыз урлаумы? Аны, ябыштырып алу, диләр...* Т.Нәбиуллин. **Ябыштырып чыгару** *к.* **ябыштырып алу**. *Кайдан ишеткәннәр ул минем Гыйбай бабайның уналты яшьлек кызны үзенә ябыштырып чыгаруын?* Г.Ибраһимов. *Нигъмәтҗан күчернең кызын ябыштырып чыгарды.* Г.Камал

**Ябыштыра бару** *к.* **ябыштырып бару**. *Газета-журналлардан тәрбия темасына язылган мәкаләләрне, кисеп алып, аерым альбомга ябыштыра барды.* Ф.Яруллин. *Күргән бер матуррак конфет кәгазен стенага ябыштыра бара.* Р.Батулла

**Ябыштыра башлау** Ябыштырырга тотыну. *Иелеп, ул белдерү ябыштыра башлады.* М.Галиев. *Ябыштыра башла, чәпчемә, кеше карап тора.* Р.Сәгъди

**Ябыштыра тору** Башка бер эшгамәлгә кадәр яки шул эш башкарылган вакытта ябыштыру; даими ябыштыру. *Бәйләвен дә көнләп түгел, купкан саен ябыштыра тордык.* Ф.Яруллин. *Шул тирәдә йөри, белдерүләр ябыштыра торгач, шаһитлар да табылды.* Кәеф ничек?

**Ябыштырып алу** Тиз генә ябыштыру, җиңел генә ябыштыру. *Өйдә бер бүлмәмә обой ябыштырып аласы бар иде.* З.Фәйзи. *Чүпрәк күбрәк булдымы, әллә салкыннан кергән көпшә үзенә ябыштырып алдымы, ул, яртылаш кереп, туктап калды.* Р.Сафин

**Ябыштырып ату** *сөйл. к.* **ябыштырып алу**. *Обой ябыштырып ату*

**Ябыштырып бару** Даими, эзлекле рәвештә ябыштыру. *Гәзитләрне көннекен-көнгә ябыштырып барырга шәһәр хакимиятенең акчасы юк иде, күрәсең.* А.Хәлим

**Ябыштырып бетерү** Барысын да ябыштыру; бик күп ябыштыру. *Икәү*

*бергә детальләрне ябыштырып бетереп, контрольгә тапшырдылар.* Х.Камалов. – *Фатирың диварларын доллар белән ябыштырып бетергәнсеңдер, – диде аңа Мөнир, шаярып.* А.Хәсәнов

**Ябыштырып җибәрү** Аз гына ябыштыру; тиз генә ябыштыру. *Син дә, егет, бераз каш ябыштырып җибәр, Шамкай сине күрсә, шатлыгыннан сөенеп үләчәк!* Р.Шәрәфиев

**Ябыштырып җиткерү** Тиешле дәрәҗәдә, тулысынча ябыштыру. *Боларны автор бары тик Сабируллaны ялгыз калдыру өчен генә эшләгән, шунлыктан ябыштырып җиткермәгән, дигән фикер кала.* М.Хәсәнов

**Ябыштырып карау** Ябыштырырга тырышу; сынау өчен ябыштыру. *Төзегән бу өйләрен югалтмау өчен, өй тирәли вак ташлар да куеп чыкканнар, өй түбәсенә тигәнәкләр дә ябыштырып караганнар.* Әкият. *Минем дә бер, ут уйнатып, тимерне эретеп ябыштырып карыйсым – шул эшне татып, белеп карыйсым килде!* Ш.Галиев

**Ябыштырып кую** Ябышкан хәлгә китерү; тиз арада ябыштыру. *Гомәр хат язылган кәгазьне пөхтәләп дүрткә бөкләде, өстәлдә яткан авиаконверт эченә тыкты да конвертның өчпочмаклы капкачын телендә шудырып ябыштырып куйды.* Г.Рәхим. *Гүя ул матур йөзне кемдер кыра-кыра каерып алган да аның урынына бака тиресе ябыштырып куйган.* Р.Габделхакова

**Ябыштырып чыгу** Һәрберсен бер-бер артлы ябыштыру. *Ася аркадагы яраларны спиртлы тампон белән чистартты, аларга яра пластыре ябыштырып чыкты.* Х.Камалов. *Җәйге аяз күк сыман зәңгәрсу обойлар ябыштырып чыккач, бүлмә иркенәеп, яңарып киткәндәй булды.* Р.Габделхакова

**ЯБЫШТЫРУЧЫ** *и. махс.* Ябыштыру эшләрен башкаручы кеше; эретеп ябыштыручы. *Ябыштыручы бит инде, Рафаэль абыйны әйтәм. Элекләрен комган төбен яматасы булса да, самавырың акса да, урак тешәтергә, сабан төрәнен чүкетергә, тырма тешләрен очлайтырга кирәксә дә, тимерчегә йөгергәннәр.* Ф.Яхин

**ЯБЫШТЫРЫЛУ** *ф. төш. юн. к.* **ябыштыру**. *Алмаз тегеннән-моннан кисеп алып ябыштырылган мәкаләләр дәфтәрен ачты.* Л.Лерон. *Ләкин җентекләбрәк күзәтә башласаң, стенага ябыштырылган кәгазьнең үтә зифа, зәвыклы икәнен күрәсең, идәнгә җәелгән келәмгә аяклар яртылаш батып китә.* Х.Ширмән

**ЯБЫШУ** *ф* 1) Җилем сыман ябыша-ябыштыра торган яки үзле әйберләр сылану, ягылып калу. *Аяк асты тайгак, үзле балчык ябышып, күн итекләр күтәрә алмас хәлгә килде, җитмәсә, бер булгач булсын дигәндәй, йөзгә бәреп яңгыр сибәли башлады.* Р.Вәлиев. *Тешләренә карамель ябышкан икән.* Сабантуй

2) Юеш булу сәбәпле, нәрсәгә дә булса сылану, сыланып берегү. *Ә яңгыр һаман коя да коя, күзләрне әчеттерә, якадан агып кереп, тәнне калтырата, юеш кием, авыраеп, тәнгә ябыша.* Р.Вәлиев. *Юешләнеп маңгаема ябышкан чәчләремне тарар-тарамас артка җыеп куйдым да, кием шкафыннан җете кызыл майкамны, кыска джинс итәгемне алып, караватка ыргыттым.* А.Әхмәтгалиева

3) Берегү, бер-берсенә кушылу, ялгану. *Нәҗип йөзтүбән яткан килеш авыр йокымсырады, керфекләре кушылып ябыштылар, тәне әз-мәз җылынса да, тездән түбән ягы салкын килеш калды.* А.Гыйләҗев. *Кайнанасы бер-ике тапкыр «кире кайтсыннар, кешедән яхшы түгел» дип чакырып караса да, географ ханым, тирәнгә кереп тормыйча гына: – Бер киселгән икмәк кире ябышмый, – дип кенә җавап бирә, ә үзен «авыр килгән бәхет татлырак була» дип тынычландыра.* Т.Галиуллин

4) Сырышу, сарылу, иярү. *Яхшыга ефәк ябышканда, яманга тигәнәк ябыша, дип, юкка гына әйтмиләрдер шул, ярар, өйгә керим, капканы бикләрсең!* Х.Ибраһим. *Джинсы чалбарыма ябышкан әрсез тигәнәкләрне алып ыргытаыргыта, ниндидер рәхәтлек белән шул бакчага таба атладым.* А.Әхмәтгалиева

5) Берәр нәрсәгә бозланып кату. *Бозланган боламыкка кашык ябышып каткан.* Г.Сабитов. *Селкенми дә басып торган Бәдриҗамалның киез итеге бозга ябышып каткан булып чыкты.* Н.Кәримова

6) Аумас, егылмас, батмас өчен, нәрсәгә дә булса тотыну. *Сигез яшьтән утау утап, унике яшеннән сәнәк тотып үскән кавемнән – бирешергә теләмәде: егылып китәм дигәндә, тәртәгә тотынып өлгерде, соңыннан чана үрәчәсенә чытырдап ябышты.* Н.Әхмәдиев. *Урман авызына чыгып җиттем дигәндә, сул аяк каядыр убылып төште, буш кул таяныч эзләп нәзек ботакка ябышты, әмма ул гына коткара алмады – учта бар яфрагын калдырып өскә атылды: Гөлйөзем йөзтүбән капланды.* Л.Зөлкарнәй

7) Гомумән кемгә яки нәрсәгә дә булса ныклап тотыну; бик нык тотынып, җибәрмичә тору. *Теге бәндә, йөгерәатлый килеп, Сакмаровның җиңенә ябыша.* Т.Галиуллин. *Бану бозауның арткы аякларына ябышып, бар көченә тарта башлады.* А.Вергазов

8) Кабаланып, ашыгып нәрсәне дә булса тоту, нәрсәгә дә булса тиз генә тотыну; кинәт тотыну; тиз генә кулга алу. *Бөтенесе дәррәү төенчекләргә, чемоданнарга барып ябыштылар.* И.Нәбиуллина. *Аучылар, сикереп торып, коралларына ябыштылар.* Р.Фәхретдинов

9) Югарырак торган нәрсәгә тотыну, асылыну, тагылу. *Әле менә Казанда мәктәп укучысының троллейбус артына ябышып йөргәнен төшереп алганнар.* Ватаным Татарстан. *Боларга кешеләрнең поездларның түбәсендә, ачык вагоннарның өстендә, вагоннарның кырыйларында я булмаса вагоннарның астына ябышып йөрү кирә.* Өмет

10) *сөйл.* Эшкә керешү, тотыну; бик зур теләк белән, бөтен игътибарны биреп нәрсәдер эшли башлау. *Ике куллап, чытырдатып, яраткан һөнәремә ябышам!* А.Гыйләҗев. *Сөйләшеп, аңлашып, озынозак кул кысышып торуны вакытны бушка уздыруга санап, шунда ук эшенә ябыша.* Т.Галиуллин // Кинәт нәрсәгә дә булса күп игътибар бирә башлау; нәрсә белән дә булса мавыгу, кызыксыну. *Әлеге детектор турында мәгълүмат биредәге халыкка Америка киноларыннан гына билгеле булганга, түрәләр, Интернет, энциклопедия кебек чыганакларга дәррәү ябыштылар.* Д.Гыйсметдин // Зур теләк белән тотыну, бик теләп, тизтиз нәрсәгәдер тотыну. *Елмаешып озаттылар да тагын тегү машиналарына ябыштылар.* Т.Әйди. *Инде кайтырга дип киенә башлаган печәнчеләр дә, кире өсләрендәге күлмәкләрен салып ташлап, сәнәкләренә ябыштылар.* Ф.Яруллин

11) *сөйл.* Берәүгә ташлану, һөҗүм итү. *Кешегә барып ябышырдай усаллыклары булмаса да, бераз күз-колак булып торырлар, төннәрен һау-һау килеп карак-угрыны куркытырлар дип, бирегә ике ата ялкау – Бим белән Сарбайны да чыгардым.* А.Хәсәнов. *Ни эшләсен: хәйран гына зур ач этне бәйдән ычкындырасы килсә дә, ябышуы бар дип уйлап, китә башлаган.* Безнең гәҗит

12) *сөйл.* Ачулану, бәйләнү; канәгатьсезлек белдерү, тәнкыйтьләү. *Язмалары-*

*на җим эзләгән тәнкыйтьчеләр дә чат ябыша аларга.* Р.Миңнуллин. *Кемнән үчен ала? Усалланып, Ач шагыйрьгә килеп ябыша ---.* Ф.Яхин // Кемгә дә булса зәһәрләнеп, усалланып, кыйнау максаты белән һөҗүм итү. *Зиннәткә Габдерәхимнең тупаслыгы ошамый иде, ул, төкереген чәчеп, аңа ябышмакчы булды, хатын сабыр гына: – Бәйләнсен, Зиннәт акыллым, бәйләнсен, – диде.* Н.Гыйматдинова. *Ыңгырашып җиргә тезләнгән Мостафа өстенә тагын эт көтүе сыман килеп ябыштылар.* В.Имамов

13) Ялгану, кушылу (сүз, фикер тур.). *Эчтеләр, капкалап алдылар, ләкин сүз ябышмый, кичәге йөгереклек юк иде.* Р.Мирхәйдәров. *Әңгәмәбез башланып китәргә генә итә, әмма сүзләребез ябышмый һәм ятышмый аптырата иделәр.* Ф.Яхин

14) *күч.* Юану, нәрсә дә булса куллана башлау, нәрсә дә булса эшли башлау; шуның белән бик нык мавыгу. *Егетнең сабырлыгы бетә, юаныч эзләп, аракыга ябыша.* Р.Габделхакова. *Нәтиҗәдә, симереп, артык авырлык җыеп, кеше дигән ялкау зат чирли башлый, даруларга ябыша.* Н.Шәрифуллин

15) *күч.* Иярү, берегү (кушамат, исем тур.). *Әһә, дим, эчтән генә, бригадир агайга кушамат ябышкан.* Г.Якупова

16) *күч.* Аерылмау, якынлыкны югалтмау; никлы бәйләнеш тоту. *Үлсәң дә, туган җиреңә ябыш.* Н.Исәнбәт. *Һавадагы торнага ымсынып, кулыңдагы чыпчыкны очыра күрмә. Шәүкәтеңә ныграк ябыш, диюем.* М.Маликова // Берәр нәрсәне югалтмас өчен яки булдыру максаты белән, бөтен көчне куеп тырышу, көрәшү. *Тешең-тырнагың белән ябыш, үзеңнеке ит.* Ф.Яхин

17) *күч.* Җуймау, уйдан-күңелдән җибәрмәү (өмет, хис-кичереш, уй тур.). *Тәмам тиленәнеп, акылны җуйганчы дип, Сәүбән бөтен җан-күңеле белән балачак хатирәләренә ябышты.* Г.Гыйльманов. *Шушы өметемә чытырдап ябышырга теләгәндәй, мин калтыранган бармакларым белән әнинең телефонын капшалап алдым.* А.Әхмәтгалиева

18) *күч.* Нәрсәне дә булса яклау, билгеле кеше, фикер һ.б.ш. ягында нык тору; билгеле карашны яклау. *[Киртәләрнең] иң зурысы – иске карашларга ябышып ятучы һәм үзләрен галим дип атаучы затларның яңарыш идеяләренә каршы чыгуы.* Безнең мирас

19) *күч.* Максатына ирешү өчен теләсә нәрсәгә риза булу, төрле алымнар куллану. *[Муллалар] казадан аман-исән котылу өчен, иң актыккы чараларга ябышалар иде.* Г.Ибраһимов

20) *күч.* Нинди дә булса максат яки йомыш белән башкаларга сораулар бирү, нәрсәдер әйтү, аралашырга теләү; аралашасы килеп бәйләнү. *Бу Фатихәттәй, ябышса, тигәнәк кебек ябыша икән.* Г.Әпсәләмов. *Бер дә бер көнне, шул гармунын тотып, урамда уйнап йөргән чагында, бездән өч-дүрт яшькә зуррак Шайтан Вагыйз дигән малай, кая, кубызыңны уйнап карыйм әле дип, сагыз урынына ябышты бит Рәдифкә.* В.Нуруллин

21) *күч.* Нинди дә булса эшкә кул яту, кулы бару; нәрсәне дә булса бик оста башкара, эшли алу. *Ә егетнең мондый эшләргә кулы ябыша икән, какканы-сукканы уңганлыгын бизи.* М.Хуҗин. *Агач эшенә дә кулы ябыша Наилнең.* Т.Нәҗмиев

22) *күч.* Килешле, ятышлы булу, туры килү, йогышу; бәйләнешле булу. *Күбесенчә, татар җырларының әүвәлге ике юлы ахыргы ике юлына һичбертөрле ябышмый.* Гали Рәхим. *Юк, Зәбир турындагы хикәят безгә ябышмый, хатын.* В.Имамов

◊ **Ябышып калу** Кайда да булса төпләнеп, яшәп, урнашып калу. *Ләкин аның Мәскәүдән китәргә нияте юк, ул хакта уйларга да ярамый, ничек кенә итеп булса да, шунда ябышып калырга иде исәбе.* В.Нуруллин. *Хәер, бик теләсә, ул да таш калага ябышып кала иде.* Н.Гыйматдинова. **Ябышып чыгу** Кыз турында: ата-ана ризалыгыннан башка, качып кияүгә чыгу. *Солдаттан исән-сау котылып калсам, ябышып чыгарга да вәгъдә биргән иде.* А.Шамов. *Алай булгач, синекечә әйтсәм, мин сезнең Әмир абзыегызга ябышып чыгып ялгышканмын инде?* В.Имамов

**Ябыша бару** Акрынлап, вакыт үткән саен ныграк ябышу. *Кайбер галимнәр болай ди: конкреция шарга әверелсен өчен, ул ниндидер токымда баткан булырга, ә бу токым шарга төрле яклап ябыша барып, аны үстерә торырга тиеш.* Кызыл таң. *Үзе дә сизмәстән, ир Маринаның ихтыярсыз корган пәрәвезенә ныграк ябыша барды.* Мәйдан

**Ябыша башлау** Ябышырга тотыну. *Ярылган эченә, ыңгырашып, ике куллап ябыша башлаган иде, Сәйфулла, тезләнгән килеш, аның кулларыннан тотып алды.* З.Зәйнуллин. *Яклаучысыз калган йортларны эзәрлекләү, талау белән генә чикләнмичә, алар ялгызак хатын-кызларга, хәтта үсмер балаларга ябыша башладылар.* Г.Гыйльманов

**Ябыша тору** Гел, даими яки әледән-әле ябышу. *Бабай бәйләнсә, чәер шикелле, ябыша тора.* Н.Дәүли. *«Үзем, үзем!» – дип, миңа кушылмаган эшкә дә барып ябыша торгач, беләкләремә дә ит кунгандай тоелды.* Сөембикә

**Ябыша төшү** Бераз ябышу; тагын да ныграк ябышу. *Язмыш кыскан саен, ул каләменә үҗәтләнебрәк ябыша төшә.* Ш.Камал. *Закирҗанның кепкасы очкан, ул ат ялына ябыша төшәрәк алга яткан, Йолдызының борын тишекләре йодрык сыярлык булып кызарып киңәйгән – ул җилдәй узып китте.* М.Мәһдиев

**Ябыша язу** Чак кына ябышмый калу. *Хәнҗәремә ябыша язган идем бит, сылу бикә!* М.Хәбибуллин

**Ябышып бетү** Тәмам ябышу; бик нык ябышу. *Бары тик яшеннең калтыранган яктысында гына Аит аның ак җәймәсе чыланып, тәненә ябышып беткәнен шәйләп алды.* Ә.Гаффар. *Әйтерсең кемдер рәхимсез тукмап ташлаган – аяк-кулларны кыймылдатып булмый, бөтен тәне ватылган, күз керфекләре эренләп ябышып беткән, әле уянып торырга ниятләгәч тә, күзләрен ача алмый җәфаланды ул.* Ф.Сафин

**Ябышып житү** Тәмам ябышу; тиешле дәрәҗәдә ябышу. *Аралар ябышып җитмәде.* Ш.Галиев. *Һәм шушы ике өлеш, асылда, бер-берсенә ябышып җитмиләр, бербөтен тәшкил итмиләр.* А.Тимергалин

**Ябышып калу** Билгеле вакыттан яки вакыйгадан соң ябышу; бөтенләйгә ябышу. *Тол дигән исем, яманаты, «аракы диңгезенә батты» дигән кара тамгасы ябышып калды!* А.Гыйләҗев. *Хәтта татар телендәге «шамакай» сүзе дә шушы Шәмәху якларыннан килгән цирк артистларына ябышып калган...* А.Тимергалин

**Ябышып киту** Билгеле моменттан алып ябышу; әкренләп ябышу; ябыша башлау. *Аларның мөнәсәбәтләре баштан ук ябышып китте, дип әйтеп булмас: кыз хат язарга вәгъдә итмәде, истәлеккә фотосын бирмәде.* Р.Мирхәйдәров. *Күп урынны алмасын, берберенә ябышып китмәсен, дисәгез, балан җимешләрен, юып киптергәннән соң, подноска тезеп туңдырырга кирәк.* Шәһри Казан

**Ябышып кую** Тиз арада ябышу. *Әмма әңгәмәдәшем белән аралашканнан*

*соң, теге өстә телгә алынган ирек янына тагын бер сыйфат ябышып куйды.* Шәһри Казан

**Ябышып тору** Гел, даими ябышу; вакытлыча ябышу. *Ул шыр ялангач килеш күл ярындагы юан чыршыга ябышып тора, чалбар балакларын, җиңнәрен сызганган әрмән егетләре, сыңарышар чиләк тотканнар да, күлдән су чумырып алып, алмаш-тилмәш аның өстенә коялар иде.* А.Гыйләҗев. *Марҗа кызлары яшьлектә татарга ябышып тора да, олыгая башлагач, тән аерыла, җан аерыла икән шул...* М.Галиев

**Ябышып яту** *сөйл. к.* **ябышып тору**. *Шәһәр баеның ике ел рәттән авылга ябышып ятуына сәерсенә халык.* Н.Гыйматдинова. *Заманалар үзгәргәч, тынды тагын, хәзер кайда яңа эш табасың, булганына шөкер итеп, кушкуллап ябышып ятарга кирәк.* К.Кара

**ЯВУ** *ф.* 1) Күктән җиргә төшү (явым-төшем тур.). *Тышта бөтен район үзәген томалап, бурый-бурый, дуамал җәйге яңгыр ява, яшен сызылып киткәндә, бөтен посёлокта электр линияләре ыңгырашып ала, урамнан, тополь мамыкларына бөялә-бөялә, күбекле ак гөрләвекләр ага иде.* М.Мәһдиев. *Дөрес, кар яуды явуын, ләкин ул бик тиз эреп бетте.* З.Мәхмүди

2) **яугыры, яусын** *теләк ф. форм.* «Рәхмәт», «ләгънәт» сүзләре белән килеп, яхшы теләк теләү, күрсәтелгән изгелеккә рәхмәтле булу яки күрсәтелгән явызлыкка рәнҗү, рәнҗетүчене каргауны белдерә. *У-ух, нәләт яугырлары! Олуг Яса әмерләрен үтәүче калмадымы?! Үтәтермен!* Г.Каюмов. *Ай рәхмәт яусын, олан, мәрхәмәтле бала икәнсең.* Г.Гыйльманов

3) *күч.* Бик күпләп һәм бер-бер артлы коелу, сибелү, очу. *Моның белән чагыштырганда фронтта өстеңә пуля явуы да чүп кенә сыман.* Н.Әхмәдиев. *Элеккеге йөзен-төсен тәмам җуйган, ядрәләр яугандай тишкәләнгән, моңсулык сарган йорт.* Р.Галиуллин

4) *күч.* Бик күп әйтелү, бирелү, җыелу һ.б. рәвештә килеп тору. *Яуса да ява бәхет кайберәүләргә.* Ф.Яруллин. *Кайда тишәргә, кайда ямарга, кайда чокырга, кайда сипләргә – заказлар ява гына.* С.Шәрипов

5) *күч.* Берәр сыеклык яки үзле матдә өстән күпләп таму. *Мин «юк» дигәч, ул дәртләнеп сөйләп китә иде: «Чынлап та бал ява, иртәнге чык белән юкә, имән яфракларын өзеп ялап йөри идек. Тукта, менә безнекеләргә кайткач, мин сине баллы яфраклар белән сыйлармын әле...» – ди иде...* Ә.Еники. *Җыеп кына бетерерлек түгел – яфраклардан бал ява.* Ш.Галиев. *Юкәләрдән бал ява, дип, Бүген бабам шатлана.* З.Мурсиев

6) *күч. шигъ.* Бөркелү, чагылу. *Күтәрелеп карамый да үзе, шулай да күреп торам: сөрмәле күзләреннән дәрт ява.* Ф.Хөсни. *Ап-ак кына гөлләр арасыннан Ак бәхетләр генә ява сыман...* Л.Шәех

**Ява бару** Бер-бер артлы эзлекле рәвештә яву; торган саен ныграк яву. *Гомеркәем каз гомере микән, Каурый ява барыр юлларга.* Р.Ягъфәров. *Юл буе кызык хәлләр турында сөйләшеп бардылар, сораулар да берсе артыннан берсе ява барды.* Көмеш кыңгырау

**Ява башлау** Яварга тотыну. *Саимә, ирен якларга теләп, арага кергән иде, пычрак үз өстенә ява башлады.* Г.Галиева. *Кайдандыр күк күкрәгәне ишетелде, яшен яшьнәп, яңгыр ява башлады.* А.Нәҗми

**Ява бирү** Бернигә дә карамастан һаман яву. *Яңгырның бик тансык чагы, ява бирсен!* Г.Бәширов. *Тик яңгырның исе китми, Ява бирә каты итеп.* Р.Вәлиева

**Ява тору** Әледән-әле яву; һаман явуын дәвам итү. *Кар, яңгыр ява тора. Җир дымны йота тора. Үлән, гөл шыта тора. Бик матур һава тора!..* Р.Харис. *Яңгыр ява, һәр көн ява тора, Юып үтә күңел керләрен.* Г.Корбанова

**Явып алу** Аз гына яву. *Менә Кулай дигән шәһәрне үтеп киттек, менә өчдүрт йорттан гына торган бәләкәй авыл юл читендә калды, коеп-коеп, яңгыр явып алды – ул ничек тиз башланса, шулай кисәктән генә туктады да.* Ә.Рәшит. *Төн йокыларын качырып телгән, һәр көн телдән төшмәгән, күңелдә канлы яра булып торган яңгыр май азагында бер явып алгач, җиңел суладылар.* Ф.Садриев

**Явып җибәрү** *к.* **ява башлау**. *Чынлабрак явып җибәрсә, машиналар гына түгел, поездлар да туктый.* Н.Измайлова. *Яңгыр явып җибәрсә, бу таудан гөрләвек буага акмый кая аксын?* А.Тимергалин

**Явып китү** Тиз генә, кыска вакыт гына яву. *Мондый көндә, беренче бөртекләр җиргә яткан минутларда, яңгыр да явып китсәме!..* А.Гыйләҗев. *Аннан соң кар явып киткән китүен дә, ә барыбер чаңгы эзләре беленеп ята.* И.Хуҗин

**Явып кую** Кинәт, бераз, бер мәртәбә яву. *Һич көтмәгәндә, бозлы яңгырлар, хәтта кар явып куя, кортлар карлыган, алма, кура җиләкләреннән мыскал да нектар җыя алмый калалар.* А.Хәсәнов. *Яңгыр яуса явып куя иде – чиләкләп, бер туктамый яшен яшьнәп күкләр күкри, хәзерге кебек сирәк-мирәк кенә түгел...* Сәхнә

**Явып тору** Гел, даими яки хәзерге моментта яву. *Сугыш барышында әсир ителеп, безнең кулга эләккән солдатлары да шул турыда әйтә, дошман ягыннан өзлексез явып торган пуля һәм снарядларның көннән-көн арта баруы да шуны күрсәтеп тора иде.* В.Нуруллин. *Өстән туктаусыз явып тора, әйтерсең күк йөзе тишелгән, аяк асты саз да чокыр, өстәвенә дөм караңгы.* К.Җәмит

**Явып узу** *к.* **явып үтү**. *Мин килер алдыннан гына яңгыр явып узганга күрә, һава гаҗәеп матур иде.* Г.Рәхим. *Әледән-әле көзге җил улаганы ишетелә, яңгыр явып уза, я кар бөртекләре коела.* Х.Ширмән

**Явып үтү** Явып китү, үтешли яву; аз гына, җиңелчә генә яву. *Ноябрь урталарында, беренче йомшак кар явып үткән көннәрнең берсендә, без ялга кайттык.* Г.Мөхәммәтшин. *Яңа гына явып үткән яңгырдан үләннәр юеш иде, җылы пар күтәрелеп, күңелләрне иркәли, агач яфракларыннан төшеп өлгермәгән яңгыр тамчылары сирәк кенә тамып куя.* Д.Каюмова

**Явып яту** *сөйл. к.* **явып тору**. *Кайчак җитез җилләр, бөтерчек кебек бер урында әйләнеп, циклонга әйләнә, һәм шул урында атналар буе яңгыр явып ята икән.* Ватаным Татарстан. *Сишәмбе көнне төштән соң тәрәзәгә күз салсак – иплап кенә кар явып ята!* Татарстан яшьләре

**ЯВЫЗ** *с.* **1.** 1) Усал ниятле, мәкерле, кара эчле, начар, яман. *Явыз сихерченең тәэсиреннән таш сынга әйләнгән кош кыяфәтендә беркавым катып торды.* М.Кәбиров

2) Кешегә каршы булган, аңа кайгыхәсрәт китерә торган; рәхимсез, шәфкатьсез. *Күңелендә һичнинди явыз ният булмыйча, җаны-тәне, бөтен барлыгы белән, булсынга дип, килгәнеңнең көен китереп, матур гына яшәп яткан бер көндә, шундый адәм әйтеп адәм ышанмаслык хәл килеп чыксын әле!* М.Хәсәнов. *Мин үземнең солдат бурычымны әнә шулай явыз дошман белән соңгы чиккә кадәр сугышуда күрдем.* З.Зәйнуллин

3) Кешегә зыян сала дип күзалланган, башка дөньяга караган явыз рухлар. *Халык кара көчләрне, явыз рухларны үз*

*исемнәре белән атамаган, аларга төрле яшерен исемнәр таккан.* А.Тимергалин. *Болгар шәһәренең иң гүзәл кызын – Алтынчәчне һәм аның иптәш кызларын нииндидер явыз көчләр урлап киткәннәр, дигән хәбәр таралды.* А.Гадел

4) Усаллык, явызлык чагылдырган, мәкер белдергән. *Аның йөзендә явыз елмаю чаткылары сизелә иде, һәм, шул шатлыгын яшермичә, ул чиләкнең берсен Әскәрев партасы янына китереп тә куйды.* М.Мәһдиев. *Ике ханым, орышка әзерләнгән җанварлар кебек, бер-берсен явыз карашлары белән сынап, телләренә ни туры килсә шуны әйтеп, кулларын алга чыгарып, күзләрен тасрайтып, якынлашканнан-якынлаша баралар.* Т.Галиуллин

5) Зәһәр, кискен, артык усал (сүз, сөйләшү тур.). *Явыз телле, нахак сүзле кеше кайчан да булса шул теле, нахагы өчен бер җәзасын күрергә тиештер ләса?* Г.Гыйльманов // Кешедән көлгән, мыскыллы, кимсетүле. *Явыз сүзләренә игътибар итмәскә тырыш*

6) Ерткыч; тешли, чага торган, үлем китерә торган. *Мескен ат сукадан туктагач, арып-алҗуы шул чиккә җитә иде булса кирәк, күз кабакларына кунган явыз чебеннәрне дә кумас иде.* М.Хәбибуллин. *Шунда тыйнак кына бер Тычкан сүз алган: «Бу тәкъдимне мин дә хуплыйм, бу, чыннан да, явыз песидән котылуның бер чарасы, песи койрыгына кыңгырау таксак, без аның килгәнен әллә кайдан ук ишетеп торачакбыз, ул күренүгә, барыбыз да качышып бетәчәкбез».* Р.Миңнуллин

7) *күч.* Кичерүе авыр булган, кыен. *Явыз язмыш белән көрәшүе мөмкин түгел икән.* К.Тинчурин. *Фәнис абыйның иҗаты мәктәп программасына кертелү, драма әсәрләренең сезоннар буе сәхнәдән төшмәве, аның төрле исемнәргә, дәрәҗәләргә лаек булуы бу дөньяга тиккә килмәве һәм юкка гына явыз сынауга дучар ителмәве турында сөйли.* А.Галимов

**2.** *и. мәгъ.* Усал кеше. *Әни кинәт елавыннан туктап калды, минем якка әйләнеп карады да: – Кайчан кайттың, явыз?* Н.Фәттах. *Көннәрдән бер көнне бу явыз үзенең бозык эшләреннән кайтып килә икән.* Ф.Яруллин

**3.** *рәв. мәгъ.* Усалланып, явызланып, дошманнарча. *Командир Якушев аңа явыз карап алды.* М.Мәһдиев. *– Ну, җылындыңмы инде? – диде Усманов, явыз елмаеп.* З.Зәйнуллин

**ЯВЫЗЛАНУ** *ф.* 1) Усаллану, зәһәрләнү, котырыну, явызга әйләнү; явызлык эшләү. *Авылга таба йөгереп китәргә куркыныч, авыл арасы бездән шактый ерак, явызланган үгез безне күз ачып йомганчы куып җитәчәк.* Г.Галиев. *Дүртенче тотылуында кулына богау салгач та качу әмәлен тапкан бәндәнең бишенче тотылуында кылганнары өчен явызланып һәм ерткычланып горурланырга көче җитмәде бугай.* М.Хуҗин

2) *күч.* Көчәю, котыру (җил, буран һ.б.ш. тур.). *Явызланмачы, җил туганкай! Син мине аркамнан сөеп-этәреп бар, мин сиңа рәхмәтемне укырмын!..* М.Хуҗин

**Явызлана бару** Торган саен ныграк явызлану. *Тормыш кырысланган саен, алар явызлана бара.* Т.Галиуллин. *Минәт кенә Шәмсүннең кызгылт чырае хәзер генә эчеп куйган аракы тәэсиреннәнме, әллә эчендә дулаган авыр уйларыннанмы торган саен явызлана баруын, күзләренә яңадан кургашын төсе иңүен чамалап, ни әйтергә белми торды.* А.Вергазов

**Явызлана башлау** Явызланырга тотыну. *Карчык явызлана башлаган, боларның икесенә дә көн беткән.* Әкият

**Явызлана төшү** Бераз явызлану; тагын да явызлану. *Хатынының балага узуы да аны тынычландырмый, ул, киресенчә, усаллана, явызлана гына төшә.* Ф.Тарханова. *Кан исеннән исергән өер исә котырганнан-котыра барды, отыры явызлана төште.* Р.Мирхәйдәров

**Явызланып бетү** Тәмам явызлану. *Милиция начальнигы булып эшләп, явызланып беткән кеше.* Р.Газиз. *Явызлыкны күрә-күрә тагын да явызланып бетәбез түгелме, берсеннән-берсе хәтәррәк вәхшилекләр арту шуның нәтиҗәсе түгелме?* Хезмәт даны

**Явызланып йөрү** Күптәннән яки гел, һәрвакыт явызлану. *Тагын ник явызланып йөри икән бу агайлар?* В.Нуруллин

**Явызланып китү** Нииндидер сәбәптән кинәт явызлану; соңгы вакытта явызлану. *Менә шул ишанга кул биргәч, бигрәк тә явызланып китте.* К.Тинчурин. *Вакыты белән телем, мине тыңламыйча, ачы тормадай явызланып китә.* Т.Галиуллин

**Явызланып тору** Гел, һәрвакыт явызлану; хәзерге вакытта явызлану. *Явызланып торма әле шундый вакытта*

**ЯВЫЗЛА́РЧА** *рәв.* Явыз кешеләргә хас булганча, усал ният белән; аяусыз рәвештә. *Ә син минем яратуымнан явызларча файдаландың да хәзер берни булмагандай йөри бирәсең!* В.Нуруллин. *Ике ай буе, бөтен эшемне ташлап, явызларча сагаладым тегене.* Ф.Садриев

**ЯВЫЗЛЫК** *и.* 1) Явыз ният белән башкарыла торган гамәл; әшәкелек; яманлык. *Изгелек эшләсәң – саваплы, явызлык эшләсәң, гөнаһлы буласың, дигән идек.* А.Хәлим. *Курыкмагыз, мин сезгә бернинди дә явызлык эшләргә теләмим.* А.Гадел

2) Кешенең характерына хас булган астыртын усаллык, мәкерлелек. *Каян шулкадәр явызлык була икән кешедә, Фәүзия?* А.Гыйләҗев. *Кайнарлыгы, ачуы-ярсуы шундук юкка чыкты, бөтен явызлыгы, бергә җыелып, кинәт каядыр эчкә төшеп китте.* Н.Фәттах

**ЯВЫМ** *и.* Җиргә яңгыр, кар, боз формасында төшә торган атмосфера күренеше. *Әле генә телефонограмма алдык: бүген төнлә явым башланачак.* М.Мәһдиев. – *Менә бүген, явым тидермичә, печәнемне кибәнгә өя алуым үзе минем өчен зур бәхет булды, – дип җавап биргән.* Н.Сәйяр

◊ **Явымнан качып (куркып), яшенгә эләгү**. Бәладән котылам дип, тагын да авыррагына, куркынычрагына тару

**ЯВЫМЛЫ** *с.* Явым-төшем күп булган; башка вакытка караганда явым күбрәк булган; корылык булмаган. *Икмәк өчен бик катылык иде ул елда, явымлы ел иде, күпме иген кырда калды, чәчүлекнең һәр бөртеге исәптә иде.* А.Гыйләҗев. *Көннең бер дә рәте юк: үзе явымлы, үзе салкын, кар төшәргә җыена, ахрысы.* М.Хәсәнов

**ЯВЫ́М-ТӨШЕМ** *җый. и.* Яңгыр, кар, боз яву күренеше; җиргә төшә торган һәртөрле явым. *Шәкерт тә хәвефләнде, явым-төшем эшне бозып куймасын тагын, дип борчылды.* М.Әмирханов. *Күбәләкләр, башка бөҗәкләр кебек үк, явым-төшем булуын кешеләргә алдан хәбәр итәләр.* Н.Каштанов

**ЯВЫ́М-ТӨШЕМЛЕ** *с. к.* **явымлы**. *Явым-төшемле көндә арбасы яки чанасы өстенә калын киндердән чатыр корып куя.* М.Хуҗин. *Хәзерге вакытта юллар коры торса да, тиздән явым-төшемле көз һәм аның артыннан карлы-бозлы кыш килер.* Туган як

**ЯВЫ́М-ЧӘЧЕМ** *җый. и. к.* **явым-төшем**. *Күкчәтау каласыннан башланган озын юл, явым-чәчем, җил-давыл, ми кайнаткыч җәһәннәм эссесе, сусызлык, ачлык, кимсетелү --- – барысы да булды.* И.Салахов. *Сикереп чыгарсың да, Аллаһы боерса, шушы борчакларны,*

*аяз көн торса, ишегалдыгызның такыр җирендә, явым-чәчем булса, өй идәнегезгә чәчеп-сибеп җибәрерсең.* Г.Мөхәммәтшин

**ЯВЫ́М-ЧӘЧЕМЛЕ** *с. к.* **явымлы**. *Башка вакыт булса, мондый явым-чәчемле көндә ат ашатып, ызбруй төзәтеп өйдә ятасың.* Г.Ибраһимов. *Шунда Тукай явым-чәчемле көннәрдә авырсынып ята.* Л.Хәмидуллин

**ЯГА** *и. диал.* 1) Берәр нәрсәнең чите, яны, буе. *Урман, үлән күренәдер, Дәхи тауның ягасы.* К.Насыйри. *Бу юлы да аты Тәмле су чишмәсе ягына борылган иде, Илфат тезгенне мәктәп яга тартты.* В.Гали

2) Чит, чит җир. *Мин белгәндә, алар каяндыр ягадан кайткан иделәр, икеөч ел гына авылда яшәп алдылар да яңадан ягага шылдылар.* К.Миңлебаев. *Әнә клубка ягадан Гали атлы егетне кайтарганнар.* Н.Гыйматдинова

3) Яклаучы; химая. *Агасы барның ягасы бар.* Әйтем

**ЯГАЛАП** *бәйл. к.* **ягалый**. *Картайган мәче башлы бер ябалак, Эзләнеп, очып йөри тау ягалап ---.* Н.Думави. *Җәйге кояшның соңгы нурлары Сакмар елгасы белән Урал бергә кушылган тарафтан кыйгачлап, җир ягалап сузыла башлаганда, без, борынгы Каргалы шәһәре белән хушлашып, кайтыр юлга чыктык.* Л.Хәмидуллин

**ЯГАЛЫЙ** *бәйл. диал.* Яныннан, буеннан. *Фәлах абзыйлар ягалый шахтёрзимагур Готфан абыйларның калай түбәле йорты күренә.* Ш.Маннапов. *Ат чаптырып, Камышлы күл ягалый кайттым мин, Рабига.* Н.Гыйматдинова // Бик якын итеп, якыннан ук, орынып. *Стена ягалый узу*

**ЯГМУР** *и. иск.* к. **яңгыр**. *Ул кичә тауда каты ягмур явып, уйсу җирләр дәрья булды, куйларны агызып китте.* К.Насыйри. *Давыл, җил һәм болыт чыкты, каты ягмур явып торды.* К.Юлдашев

**ЯГУ** I *ф.* 1) Ут төртү, кабызу. *Мичне ягып җибәрү*

2) Җылылык, яктылык чыганагы булсын өчен яисә су кайнату, ашарга пешерү максаты белән утын, ботаклар һ.б.ш. яндыру. *Шырлап ага торган чишмәдән салкын суны алып, минем юл чәйнегемә салып, ут ягып, чәй кайнаттык.* Г.Исхакый. *– Үзебездә чакта, без дә менә шулай учак яга идек, – дип дәвам итте сүзен баш кунак, моңсу гына елмаеп.* З.Мәхмүди

3) Күмер, утын кебек нәрсәләрне ягулык итеп куллану. *Алар кайтмаган елларда атау читендәге корыган талларны кисеп яга.* Р.Вәлиев. *Бездә бит хәзер бар җирдә дә газ ягалар.* Р.Зарипов // Бинаны җылыту. *Өй күптән ягылмаган*

4) Юк итү өчен, кирәкмәгән нәрсәләрне, иске әйберләрне һ.б.ш. яндыру. *Өеп-өеп яктык китапларны, Йөз чөердек – кемнән җирәндек?* Х.Әюп

5) Мичен кабызып җибәреп, мунчаны бик нык җылыту, юыну өчен әзерләү. *Хәзер мунча яга башлау белән: «Мияу, мияу!» – дип, аяк арасында бөтерелә башлый.* А.Хәсәнов. *Мунчасын да газ белән яга, җиләген дә, кырын ятып кына, тау битләреннән чүпли иде.* Н.Гыйматдинова

6) *күч.* Дәрт, ялкын кабызу, ярсыту. *Тормыш йөге белән телгәләнгән Йөрәгемә утлар яксаң да, Дулкынланып йөргән чакларымда Уйларымны кире каксаң да.* А.Алиш

**Яга бару** Бер-бер артлы, барысын да рәттән ягу. *Утын беткән саен яга барганга, бу читәннәр дә бетеп бара иде.* Г.Ибраһимов

**Яга башлау** Ягарга тотыну. *Шуңа күрә безнең халык иң беренче кияү мунчасы яга башлаган...* Р.Батулла. *Көннәр инде шактый салкынайган булса да, мәктәпкә әле яга башламаганнар иде.* В.Нуруллин

**Яга тору** Алдан ягу; озак вакыт дәвамында ягу; даими ягу. *Исән-сау кайта, бәлешеңне әзерләп, мунчаңны яга тор!* Р.Батулла. *Дөрес, икешәр морҗалы кешеләр әлеге салкын өйләрне утынга сүтеп яга торалар.* К.Кәримов

**Яга төшү** Тагын да ныграк ягу. *– Утынны кызганма, яга төш, – ди икән моңа Убырлы карчык.* Әкият

**Ягып бару** Эзлекле рәвештә ягу; булган берсен ягу. *Минем хатларны кешегә укытма. Ягып бар.* Р.Зарипов. *Әнисе аның дини кеше булганга күрә, хатларны саклау – гөнаһ дип, аларны ягып барган.* Салават күпере

**Ягып бетерү** Барысын да ягу; беткәнче ягу. *Авыл советы председателе Гыймадиевларның ишегалдыннан ничә чана каен пүләннәре алып кайттык, өй түбәсендәге саламга кадәр ишеп ягып бетердек – җитә белмәде!* К.Булатова. *Хәлим якын-тирәдәге бөтен ягардай әйберне ягып бетерде, әмма, утын юк дип кенә, учакны сүндерәсе килмәде аның.* Г.Гыйльманов

**Ягып җибәрү** *к.* **яга башлау**. *Шул ният белән ул учакка ут ягып җибәрде дә гадәтенчә кухня тирәсендә кайнашырга тотынды.* Н.Фәттах. *Инеш буендагы корыган тал ботакларын җыеп учак ягып җибәрсәм, ничек шәп булыр иде, диеп уйлады.* Г.Галиев

**Ягып кую** Алдан ягу; ягылган хәлгә китерү. *Әле ярый, мичкә шәпләп ягып куйган идем.* А.Гыйләҗев. *Егетләргә мунча ягып куярга әйткән идем, шуңа күрә Чулпанны, киемнәрен дә салмаган килеш, туп-туры мунчага җибәрдем.* Х.Ширмән

**Ягып тору** Гел, даими яки хәзерге моментта ягу. *Өйдә тәмле ризыклар пешереп, мунча ягып торырга Хәдичә апасын калдырды.* Г.Галиева. *--- туктаусыз ягып торсаң да, өч еллык утыны бар өстенә, шул малай әнә тагын бер машина шыңгырдап торган каен утыны алып кайткан.* В.Нуруллин

**ЯГУ** II *ф.* 1) Нәрсәнең дә булса өстенә май, бал, кайнатма кебек йомшак яки үзле масса сөртү. *Ут ягабыз, кечкенә малаебыз инде зәңгәрләнеп беткән, очкылык тота, эш алга бармый, гел хатын белән сугышабыз, ул арада тамак ача, салкын җилдә, учак янына утырып, май яккан, җилләгән ипи капкан булабыз ---.* М.Мәһдиев. *Балдыз каймаклы ипигә бал ягып ашарга бик ярата.* Ф.Яруллин

2) Биткә буяу, кершән, крем, грим һ.б.ш. сөртү. *Мин әле сөрмә тарта, пудра яга белмим (дөресрәге, кирәген тапмыйм), әмма хушбуйның бик нәфис ислесен сөртергә яратам.* Ә.Еники. *Кырык төрле майларны килолап алып, битенә, тәннәренә яга, иннек, кершән, сөрмә ише нәрсәләрне бергә җыйсаң, кибет ачарлык.* К.Кара

3) *күч.* Берәүнең гаебен, гаепле эшен икенче кешегә күчерү, сылтау, аудару. *Төркидә кыз урлау гомер бакыйдан килә, әмир әнә аны да аңа яга.* М.Хәбибуллин. *Сез ничек шундый яла яга аласыз?* Ф.Садриев

**Яга башлау** Ягарга тотыну. *Изаел ипи телеменә сөт өсте яга башлый.* Р.Гаязетдин

**Яга тору** Башка бер эш-гамәлгә кадәр яки шул эш башкарылган вакытта ягу. *Ул ипигә май яга тора, мин балык кисәм.* Сабантуй

**Яга төшү** Тагын да ныграк, күбрәк ягу. *Буяуны яга төшәргә кирәк*

**Ягып бару** Эзлекле рәвештә ягу; бер-бер артлы һәрберсенә ягу. *Аскы катламны калынрак итеп, аннан соң-*

*гыларын юкарак итеп, араларына эчлек ягып барып, пирогны ясыйсың.* Көмеш кыңгырау

**Ягып бетерү** Барысын да ягу; беткәнче ягу. *Һәр катны крем белән сыларга, ә иң өскә калган барлык кремны ягып бетерергә.* Сөембикә

**Ягып җибәрү** Тиз арада ягу; яга башлау. *Ипи өстенә май ягып җибәр, шикәр комы сип, бик тәмле була ул, без шулай ашый идек.* Сөембикә

**Ягып кую** Алдан ягу; ягылган хәлгә китерү. *Кичке шәфәкъларда тәрәзә пыялалары кан ягып куйганга охшап калалар, бер иялэшкәнче, күңелне гелән шом биләп ала торган иде.* М.Хәсәнов. *Иреннең чия кызылын кәгазь киптергечкә күчереп бетергәч, ул яңадан кызгылт көрән иннек ягып куйды.* К.Кәримов

**Ягып тору** Гел, даими яки хәзерге моментта ягу. *Грим да ягып торасы юк, тот та Кармен роленә билгелә.* М.Юныс

**ЯГУЛЫ** *с.* **1.** Ягылган; ягып җылытылган; җылы хәлгә китерелгән. *Өстәлендә самавыры җырлап, миче ягулы булып торган йорт элекке ямен югалтты.* Р.Рахман. *Кунак чакыргансың икән, мунчаңа тикле ягулы булсын, ди бит безнең халык.* Мәдәни җомга

**2.** *хәб. функ.* Ягылган булу. *Мунча ягулы, аш хәзер иде.* Г.Ибраһимов. *Яхшы кешеләргә учагым ягулы, казаным асулы.* Н.Фәттах

**ЯГУЛЫК** *и.* 1) Утын, күмер, торф, газ һ.б.ш. кебек, янып, җылылык бирә, биналарны, торакларны җылыту өчен кулланыла торган матдәләр. *Беренчедән, шундый зур шәһәр өчен алар бик аз, икенчедән, булган кадәресенә дә ничек ягулык җиткерергә?* З.Мәхмүди. *Иң катлаулы авыруларны карау, табибларның булдыксызларын эшкә өйрәтү өстенә, бинаны төзекләндерү, кышка ягулык белән тәэмин итү, рентген, УВЧ аппаратларын кайтарту кебек бихисап мәшәкать аның бөтен вакытын, көчен йота.* М.Маликова

2) Нефть, бензин, керосин яисә уран, плутоний кебек, двигательләрне, реакторларны эшләтү өчен кулланыла торган матдәләр. *Унике тонна сыешлы бу олы мичкәдә техника өчен ягулык йөртелә иде.* И.Хуҗин. *Аллага шөкер, быел да ягулык, запчасть табып, язгы кыр эшләренә вакытында чыктылар.* З.Мурсиев

**ЯГУЧЫ** *и.* Мич ягып, бинаны җылыту вазифаларын үтәүче кеше. *Икәүләшеп, гади һәм авыр тормышта яшәп, һәрдаим өстәмә эшләрдә эшләп, әтием әле каравылчы, әле ягучы яки итекче булып, әни һәр басма бит өчен 20 тиен акча белән өстәмә эш алып, Урал елгасы ярында, шәһәрнең Бохарага китә торган ягында менә дигән йорт җиткереп, дүрт угыл тәрбияләп үстерделәр.* Т.Кәримов. *Бабасы соңгы елларда ягучы булып эшләгән икән.* Кызыл таң

**ЯГЪНИ** *терк.* Өстәмә аңлатма бирә торган җөмләне яки җөмлә кисәкләрен теркәү өчен кулланыла. *Төтеннән качып, бала-чагалар, ягъни Мәхмүтҗан бабайлар, өйдә генә ятканнар, имеш.* Н.Фәттах. *Сөйләшкәннәре булмаса да, исәнләшеп йөриләр, ни әйтсәң дә якташлар һәм өстәвенә адашлар, ягъни фамилиядәшләр бит.* А.Тимергалин

**ЯГЫЛБАЙ** *и. зоол.* Лачын кошлар семьялыгыннан Евразиянең урман һәм урман-дала зоналарында яши, Африкада кышлый, бөҗәкләр һәм вак тычкансыман кимерүчеләр белән туклана торган ерткыч кош; төн лачыны; *русчасы:* **кобчик**. *Сыерчыкның тубына Ягылбайны чөегез; Сусасагыз уенда, Әнә, ак су эчегез.* Дастан

**ЯГЫМЛЫ** *с.* **1.** Сөйкемле, күркәм, матур; күңелгә ятышлы. *Әминәне ул көләч, һәрчак шат йөзле булуы өчен яратты, Фатыйма инде үзенең утә ягымлы булуы белән аның күңелен үзенә тартты.* А.Алиш. *Рәшат, ымсынып, кыздан ягымлы сүз, теләктәшлек көтә иде, ә Луизаның күзләрендә чамасыз ачу гына кайный иде.* А.Гыйләҗев

**2.** *рәв. мәгъ.* Ачык йөз белән; күңелгә ятышлы итеп; матур итеп. *Гөлшәһидә Мортаза бабай белән ягымлы итеп исәнләште, хәлен сорашты.* Г.Әпсәләмов. *Каршылавын да хәйран ягымлы каршылады.* В.Нуруллин

**ЯГЫМЛЫЛАНУ** *ф.* Ягымлыга әйләнү. *Ләкин, шул вакыт ишек яңадан ачылып, бүлмәгә икенче берәү килеп керде, һәм әле генә төкерек чәчеп җикеренгән чиновникның тәкәбберлегә шундук юкка чыкты, бөтен йөзекыяфәте ягымлыланып, күндәм, буйсынучан бер төс алды.* М.Галәү. *Шундый ягымлыланган, шундый тәмле теллегә, итагатьлегә әйләнгән – шаклар катарлык иде.* В.Нуруллин

**Ягымлылана бару** Торган саен ягымлылану. *Әнинең кисәтүле тавышы ерагайган саен ягымлылана бара.* М.Галиев

**Ягымлылана башлау** Ягымлылык билгеләре сизелү, күренү. *Кыз ягымлылана башлаган*

**Ягымлылана төшү** Бераз ягымлылану; тагын да ныграк ягымлылану. *Егерме бишлекне күргәч, хатынның салкын йөзендәге боз эреп киткәндәй булды, ул Искәндәргә ихтирамлы караш ташлады, тавышы да йомшара, ягымлылана төште.* Р.Вәлиев

**Ягымлыланып калу** Берәр сәбәптән, ниндидер тәэсирдән, вакыйгадан соң ягымлылану. *Шешәләрне кулына алу белән, аның йөзе балкып китте, тавышы йомшарды, күз карашы, беркайчан да булмаганча, нурланып, ягымлыланып калды.* Н.Фәттах

**Ягымлыланып киту** Билгеле бер вакыттан ягымлылану; кинәт ягымлылану. *Мин аның калын иреннәренә, берьюлы ягымлыланып киткән йөзенә исем китеп карап торам.* А.Гыйләҗев. *Кычкырып көлгәндә яшьләнеп, үзенә бертөсле итеп ягымлыланып китә торган коңгырт күзләр.* Ф.Яруллин

**ЯГЫМЛЫЛЫК** *и.* Мөлаемлык, күңелгә ятышлылык, матурлык. *Коньяк కояшында янып беткән бу кыска чәчле ябык кызның күгелҗем күзләрендә тел ачтырмый торган ягымлылык белән кырыслык бергә кушылган иде кебек.* Г.Әпсәләмов. *Балага күчкән бу елмаю үзенә бер ягымлылык, матурлык тудыра.* Г.Галиева

**ЯГЫНУ** *ф. кайт. юн. к.* **ягу**. *Беркөнне шул асрау, абыстайлары өйдә юк чагында, барган да минем Гафифәнең пудраларын алып ягынган.* Г.Камал. *Иннеккершәнне мул итеп ягынганнарының битләре тирләп чыккан, берөзлексез җилпәзә җилфердәтәләр.* Г.Тарханова

**Ягына башлау** Ягынырга тотыну. *[Зөбәйдә:] Әй, аптыратма әле, Әсхәт! (Көзге алдына килеп, пудра ягына башлый.) Кил монда!* Ш.Хөсәенов

**Ягына тору** Башка бер эш-гамәлгә кадәр яки шул эш башкарылган вакытта ягыну. – *Пудра ягына тор алайса, мин хәзер керәм, – дип, тиз генә чыгып китте апасы.* Идел

**Ягынып бетерү** Беткәнче ягыну; бик күп ягыну. *Ә ул әле һаман пудра ягынып бетерә алмый, пудра ямьсез төште дип, яңадан битен юып ята.* Г.Камал. *Пүчтәктән генә «Нива» белән «Колос» комбайннары иннек ягынып бетермәгән кыз төсле утыралар, мәйтәм.* Б.Камалов

**Ягынып җибәрү** Бераз ягыну. *Болар барысы да ул серкәле башны җилкендерү өчен җитә кала: битенә кершәнинек, тырнакларына кына ягынып*

*җибәрә кызый, өстендә әлеге зәңгәр плюш бишмәт, әйтмәссең теге вакыттагы йомыкый Камәр, дип.* Ф.Хөсни

**Ягынып тору** Хәзерге моментта ягыну; шактый вакыт ягыну. *Грим ягынып торганда: «Ә син дулкынланасыңмы соң?» – дип сорап куйды ул.* Сәхнә

**ЯД** *и. фар.* 1) Хәтер; истә тоту сәләте. *Ишек ачу дигән эш ядларына керептә чыкмый.* Ш.Камал

2) Истәлек, хатирә. *Хезмәтенә мең кат иеп башымны, Яд язармын аңа бары соң чиктә: «Актан койдыр... – диеп, – кабер ташымны».* Ф.Гыйззәтуллина. *Мин яд белән карыйм үткәннәргә: Гомеренең хәләл һәр тамчысын Гыйлем эстәп фида иткәннәргә.* С.Әхмәтҗанова

◊ **Ядка алу** 1) Ятлау. *Тырышты, тырмашты, Коръәнне ядка алып бетерде.* Г.Исхакый. *Боларга тагын әсирләр лагеренда А.Алиш белән аралашкан һәм аның кайбер шигырьләрен ядка алып, хәтерләрендә саклап кайткан элеккеге әсир Газыйм Кадыйров һәм Тәлгать Гыймрановларның күчермәләрен --- өстәргә мөмкин.* Р.Даутов; 2) Аңны баету, өйрәнү, зиһенгә алу. *Заман хәзер мәгърифәткә атланырга, Төрле фәннәр, гыйлемлекләр ядка алырга ---.* Г.Камал; 3) Искә алу, искә төшерү. *Ибрайларны ядка алып утырасызмы?* М.Фәйзи. *Ташбилгем дә калмас, бәлки, ядка алып еларга.* З.Мансуров

**ЯДА́У** *с. диал.* Ябык, хәлсез, йөдәү. *Узелчылар нидән ядау – Бөгелеп узел ташыйлар.* Һ.Такташ. *Болай да ядау атларны коры сөяккә калдырмассың бит.* М.Хуҗин

**ЯДӘЧ** *и.* Кошларда дугасыман бөгелгән күкрәк сөяге. *Мочтакбай, ядәч тоткан кулын төшермичә генә, икенче кулындагы касәне югары күтәрде.* Р.Батулла. *– Истә, истә! – дибез, гүя ядәч кулда, Оттырмаска инде безнең исәп алда.* Г.Әхтәмова

◊ **Ядәч аеру** Отыш уены: ике кеше ядәчне аера да, шуннан соң, «исемдә» сүзен әйтмичә, бер-береннән бер әйбер дә алмыйлар; әгәр алганда берсе ул сүзне әйтергә онытса, әйбер биргән кеше «ядәч» дип әйтә һәм ота. *Минем аның белән ядәч аерганым юк лабаса.* Л.Ихсанова. *Кичә генә әйбер тоттырудан ядәч аерган идек. Тәки отты бит, чукынчык!* И.Хуҗин. **Ядәч аерышу** *к.* **ядәч аеру**. *– Әйдәгез, кем белән ядәч аерышабыз? – диде.* Ә.Еники. *Әти, әйдә, ядәч аерышабыз.* Г.Сабитов

**Я́Д ИТҮ** *ф.* Искә алу, искә төшерү, хәтергә китерү; телгә алу. *Туктал, сөйлә, яхшы сүз белән яд итик аларның исемнәрен...* А.Гыйләҗев. *Авылда аларның каберләрен яд итәрлек балалары да калмаган бугай.* А.Хәлим

**ЯДКӘР** *и. фар. кит.* 1) Хатирә, истәлек. *Ни калдырдык җиргә ядкәр итеп?* К.Булатова. *Шушы затка ядкәр буларак, Риза Фәхретдиновның әтисе тууга, аңа «Фәхретдин» исемен биргәннәр.* Ф.Яхин

2) Истәлеккә бүләк ителгән әйбер; истәлекле бүләк яки кемнән дә булса калган истәлекле әйбер, сувенир; реликвия. *Гаилә ядкәре булган, асылташлар белән бизәлгән хәнҗәрне кара кайгыга калган Хәсәнҗанның кулларына тоттыра.* В.Гали. *Сугыш кырыннан килгән хатларны әле дә булса сандык төбендә ядкәр итеп саклый.* Р.Зарипов

3) Тарихи истәлек; әдәби яки мәдәни мирас объекты; ядкәрлек. *Һәрберсе архитектура ядкәре булырлык бу йортларны төрек төзүчеләре салган, Салехардны, әр-яңадан, алар төзегән.* Ф.Бәйрәмова. *Ядкәр белән танышканда, иң әүвәлдә, әсәрнең берничә исем белән бирелүе берникадәр аптырашта калдыра.* Ф.Яхин

**ЯДКӘРЛЕК** *и.* 1) *к.* **ядкәр** (*2 мәгъ.*). *Гаилә ядкәрлеге. Борынгы ядкәрлек*

2) Мәдәнияттә, көнкүрештә һ.б.ш. элекке буыннардан, үткән чордан калган мирас, тарихи истәлек. *Безнең тарихи-мәдәни ядкәрлекләрдәге традицион сәнгать кыйммәтләрен күрсәтү, пропагандалау эшендә дә яңа алымнар кертү кирәктер, республикабызның күп кенә музейлары квалификацияле ярдәмгә мохтаҗ.* Р.Вәлиев. *Й.Баласагуниның «Кутадгу билик» дигән поэмасы күләме ягыннан да, эчтәлеге җәһәтеннән дә, тарихи ядкәрлек буларак та төрки дөньядагы иң күренекле сәнгатьчә әдәби әсәр булып тора.* Фәнни Татарстан

3) Тарихи, мәдәни һ.б.ш. ядкәрләр тупланмасы; шуларны саклау урыны. *Туристик үзәктә, үз чиратында, тарихи ядкәрлекләр, кунакханәләр, рестораннар, кафе, күңел ачу урыннары турында тулы мәгълүмат алып була.* Мәдәни җомга

**Я́Д КЫЛУ** *ф. к.* **яд итү**. *Ә испаннар үлем турында аны яшәүнең бер кисәге итеп язалар һәм... үлгәннәрнең кадерен беләләр – пантеоннар төзиләр, яд кылыр өчен сарайлар торгызалар, һәйкәлләр куялар.* Р.Фәйзуллин. *Моңа батырчылык иткән (тыелган тема!) А.Чеховны хөрмәт белән яд кылырга гына кала.* Ф.Галимуллин

**ЯДРӘ** *и. рус* 1) Утлы коралдан ату өчен, кара кургаштан ясалган вак кына шарчык. *Шул, фин солдатлары эчтән ядрә үткәрми торган резина күлмәк кияләр икән.* Т.Гыйззәт // Пуля. *Ядрә аның сул кулының уч төбенә кергән, кул сыртыннан чыккан.* Р.Батулла

2) Туптан ату өчен коеп ясалган шар формасындагы снаряд. *Күпме үлемнән, ядрә, снарядтан исән калып та, шушы яшьтә, шушындый тыныч, матур тормышта көтмәгәндә арабыздан китеп баруың һич кенә дә башка сыймый.* Н.Әхмәдиев // Гомумән снаряд. *Артларында әйтерсең лә ядрә шартлады, тау ярылып китте.* Ф.Бәйрәмова

3) *күч.* Шарчык формасындагы һәртөрле йомры әйбер. *Базарда сатылмый яткан йомыркалар боз ядрәләренә әверелде.* К.Кәримов. *Әстерханның татлы ядрәләрен Саклык белән генә ашагыз ---.* А.Нәҗми

**ЯДРӘЛЕ** *с.* Ядрә (*1 мәгъ.*) белән ата торган. *Берсе иңенә куян аскан, икенчесе суер аткан иде, поши күргәннәр, тик ядрәле мылтык белән аңа якынлашып та маташмаганнар икән.* М.Ихсанов. *Минә шуның үчен алу өчен, ау мылтыкларын бик вак ядрәле патроннар белән корып, чыпчыкларны атарга, дигән тәкъдим әйттеләр.* К.Рәхим

**ЯЗ** *и.* 1) Кыш белән җәй арасындагы ел фасылы. *Тыштан җиңел һава – яз һавасы бөркелеп керде.* А.Алиш. *Тик язлар җитеп, карлар эрегәч, Гәүһәриягә әллә ни булды: күзләрендә яңадан очкын кабынды, күңеле, дәртләнеп-иләсләнеп, нидер көтә башлады.* Г.Әдһәмова

2) *күч.* Яшьлек, гомернең матур, шат һәм рәхәт чагы. *Язлары үткән, җәйләре үткән, ичмасам, көзләре дә түгел хәзер, салкын кышлары җиткән.* А.Гыйләҗев. *Гомер язы гөрләп узып киткән, Ә көзенә әле иртәрәк.* М.Сәгъдиев

**Я́З ГӨЛЕ** *и. бот., диал.* Нәүрүз гөле, нәүрүзгөл; *русчасы:* **первоцвет**. *Кар эрү белән, республика территориясендә беренче чәчәкләр баш төртә. Шулар арасында нәүрүзгөл дә бар. Аны «бадъян чәчәк», «яз гөле» дип тә йөртәләр.* Кызыл таң

**ЯЗГЫ** *с.* Язга мөнәсәбәтле; яз көне була торган. *Караңгыда, язгы пычракта, кар суларына бата-чума ике-өч сәгать эзләгәннән соң гына, Мансур бу аркылы тыкрыкны таба алды.* Г.Әпсәләмов. *Болай булса, язгы чәчүне ничек*

*тә вакытында ерып чыгарбыз дип, эчтән куанып йөри идем.* В.Нуруллин

**ЯЗГЫ́-КӨЗГЕ** *с.* 1) Яз һәм көз айларында була торган; яз һәм көзгә мөнәсәбәтле. *Язгы-көзге пычракларда, әлләниләр урасаң да, су үтеп керүдән котыла алмыйсың.* К.Җәмит. *Авыл хуҗалыгында ул язгы-көзге кыр эшләрендә еш кабатланса, төзелештә җәй айларында күп теркәлә.* Кызыл таң

2) Яз һәм көз кия торган. *Аксыл пиджак эчендәге соры күлмәк һәм кыйгач буйлы галстук – яңа, кара чалбары җиренә җиткереп үтүкләнгән, муенында ак шарф, күлмәккә тартымрак төстәге язгы-көзге пальто белән йонлач бүрек тә үзенә килешә, кулында кара күн пирчәткә – барысы да кешелеккә кия торган.* Р.Кәрами. *Гомеремдә беренче тапкыр язгы-көзге аяк киемен кибеттән алдым быел.* Безнең гәҗит

**ЯЗГЫЛЫКТА** *рәв. диал.* Яз көне, язын. *Язгылыкта чәчү эшләрен тәмам иткәннән соң, бәрәкәтле яңгырлар шәфкатеннән ташламасын, уҗымнар дәррәү калыксын, игеннәр җәй буе күкрәп үссен, дигән теләкләрен күкләргә җиткерү нияте белән, авыл халкы елның елында Коръән ашы уздыра.* Шәһри Казан. *Бакча өчен җире булды, тик юл юклыгы язгылыкта ачыкланды.* Туган як

**ЯЗДЫРУ** I *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **язу** I. *– Китап тотуга минем күзләр әлҗемелҗе килә башлый, колаклар кызыша, – ди иде, тора-бара мавыгып китте, китапханәдән үзе китаплар яздырып алып укый башлады.* Ф.Яруллин. *Бәлки, моңа телефоннан әйтеп яздырганнардыр әле.* А.Тимергалин. *Чынлап торып еласаң, сукыр күздән яшь чыгар, дигәндәй, тырыша торгач, Айсинәдән тәки гариза яздырдылар бит.* Н.Кәбәш

2) *к.* **язылу** I (*3 мәгъ.*). *Көннәр буе өйдә утырып ялыкмасыннар, күңелсезләнмәсеннәр дип, унбиш төрле мода журналы яздырдык үзләренә, ике көн саен бер журнал килеп кенә тора.* Г.Рәхим. *Дөнья сулышын бик яхшы тойган, Казаннан гына түгел, Мәскәүләрдән дә газета-журналлар яздырып алып яткан Асылгәрәй хәзрәт эшләрнең кая таба барганын яхшы аңлый иде.* Ф.Бәйрәмова

3) Тавышны яки күренешне аудио-, видео- һ.б.ш. аппарат ярдәмендә теркәү, магнитлы тасмага яки цифрлы хәтергә салу. *Ул үзе Нәҗип магнитофонынннан Тәнзиләнең җырлавын яздырып алган.* Н.Акмал. *Шул алтын фондка кирәклек әсәрләрне заманында яздырып алып, бүгенге көндә саклыйбызмы икән?* Р.Вәлиев

**Яздырып алу** Тиз генә, тиз арада яздыру. *Үзенекене дә булалмады, Айгөлгә дә булмасын дип, күрше авылның сихерче Марусясыннан сихер яздырып алып, Мөкаддәсне бозды.* Д.Салихов. *Төрле уңай белән стена газетасы өчен шаян шигырьләр дә яздырып алалар Хәмәттән...* М.Вәлиев

**Яздырып җибәрү** Тиз генә яздыру. *Җыр яздырып җибәрү*

**Яздырып йөрү** Озак вакыт дәвамында яки хәзер яздыру. *Синең иҗатыңа зур ихтирам күрсәтеп, иң җитди эшләреңнең берсе санап, «Яшьлегем тугае»н пластинкага яздырып йөрүен дә хәтерлим әле.* Э.Шәрифуллина

**Яздырып калу** Яздырырга өлгерү; моментыннан файдаланып яздыру. *Шушы сөйләшүне, магнитофон тасмасына яздырып калган кебек, кабат-кабат күңелдән кичерәм.* М.Вәлиев. *Монысын синең бәләкәч кызың Фәрдия яздырып калган, диярсең, яме?* Р.Сәгъди

**Яздырып килү** Күптәннән, әллә кайчаннан бирле даими яздыру. *Гади генә каникул турындагы сочинениене безгә кечкенә сыйныфлардан ук яздырып киләләр иде.* Идел. *Электән укыган газета-журналларымны да яздырып киләм, яңа китапларны да укыйм.* Татарстан яшьләре

**Яздырып кую** Алдан яздыру; яздырып эшен бетерү. *Икенчесе, үзен алыштырачакларын белгәч, фермер хуҗалыкларына ярдәм итәм, дигән булып, мең төрле хәйләләр белән, авыл хуҗалыгы техникасын бертуган энесенә яздырып куйды.* З.Мурсиев. *Гадәттә туры эфирда бара торган тамашаны алдан яздырып куярга уйлавы да шунландыр.* М.Кәбиров

**Яздырып чыгу** Һәрберсенә яздыру; бер-бер артлы яздыру. *Андый мәрмәр такта рөхсәт ителсә, иң элек Миңлекәев абый стена саен үз исемен яздырып чыгар иде әле.* Г.Әпсәләмов

**ЯЗДЫРУ** II *ф. йөкл. юн. к.* **язу** III. *– Бу Маһирә Хәбировна чыннан да мине акылдан яздырырга уйлый, ахрысы, – диде ул, күңелсез генә.* Г.Әпсәләмов. *--- әдәбиятны яратып, чыккан һәрбер китапны дип әйтмим, кайберсен булса да укып, көндәлек матбугатта басылган шигырьләрне күздән кичереп баручының, һичшиксез, үз фикере була, андый укучыны берни дә юлдан яздыра алмый.* Б.Рәхимова

**Яздыра башлау** Яздырырга тотыну. *Яшьлегендә аны рәнҗеткән ир-аттан үч алырга сүз биреп, гаиләле ирләрне юлдан яздыра башлый ул.* Безнең гәҗит

**Яздырып бару** Акрынлап яздыру. *Нинди яхшы кешене юлдан яздырып бара...* Г.Мирһади

**Яздырып бетерү** Тәмам яздыру; бик нык яздыру. *Кызларны акылдан яздырып бетергәнсеңдер инде, чибәр син, Әхмәтсафа!..* Ф.Сафин. *Үзебез дә гаепле: табиб күзенә яхшырак күреним дип, затлы аракы, аннан акча төртәтөртә, өметле, сәләтле табибларны бозып, юлдан яздырып бетерәбез бит инде.* Хезмәт даны

**Яздырып йөрү** Озак вакыт дәвамында яздыру; һәрвакыт, гел яздыру. *Карчык бик явыз икән, ди, гомер-гомергә яхшы кешеләрне аздырып, батырларны юлдан яздырып йөргән, ди.* Әкият. *Университетның иң чибәр кызы – бөтен егетләрне акылдан яздырып йөргән Диләрә.* Шәһри Казан

**Яздырып тору** Әле, хәзер яздыру; гел яздыру. *Юлдан яздырып торучылар күп хәзер*

**ЯЗДЫРУ** III *ф. йөкл. юн. к.* **язу** IV. *Әле менә бүген, җир казып арыгач, бераз бил яздырып кайтыйк дип, дачабыз янындагы урманга чыктык.* Ш.Маннапов. *Һәр көнне иртә белән Талхәветдин, сыгылып-бөгелеп, тәнен яздырырга күнегүләр ясарга бик ярата.* А.Хәлим

**Яздырып алу** Тиз генә, тиз арада яздыру. *Арбада утыра-утыра аяклары оегач, буыннарын яздырып алу өчен, юл буендагы базарга туктарга булдылар.* А.Хәлим

**Яздырып җибәрү** Тиз генә яздыру; бераз яздыру. *Гимнастика тәнне генә яздырып җибәрми, кәефне дә күтәрә.* Кызыл таң

**ЯЗДЫРУ** IV *ф. йөкл. юн. к.* **язу** V. *Казанга алып бару өчен, май яздырырга керештеләр.* М.Хәсәнов

**Я́З ЙОЛДЫЗЫ** *и. бот.* Мәкчәләр семьялыгыннан абагасыман яфраклы, сабак очында чукка тупланган сары, ал, шәмәхә, күк яки ак чәчәкле, чәчәкләрендәге нектарны озын борынлы бөҗәкләр генә суыра ала торган күпьеллык үләнчел үсемлек; сәрдәнә; калфакчәчәк, кыр бәрәңгесе, урман бәрәңгесе; *русчасы:* **хохлатка**. *Яз йолдызы чәчәкләрен бал кортлары сырып алган*

**ЯЗЛЫГУ** *ф.* Нинди дә булса юлдан, планнан тайпылу; ялгыш китү, хаталану. *Тайпылу димәк, ул туган чагында ук*

*маңгаена язылганнан язлыкмаган затлардан.* М.Хуҗин. *Яз язлыгып, ничек соңлап йөри ---.* И.Киньябулатов

**ЯЗЛЫЙ** *рәв. диал. к.* **язын**. *Кышлый, язлый үзенең тракторына я сәнәк, я көрәк, я пычак тагып эшләгән Мөбаракшин Равил хәзер чүмеч белән амбар хуҗалыгында ашлык төяп тора.* Р.Зарипов. *Китә казлар, китә казлар, Без кайтырбыз язлый, дип.* М.Саттаров

**ЯЗЛЫК** *с.* **1.** Язга җитәрлек, яз өчен билгеләнгән, язга калдырылган. *Кыш чыкканчы язлык калырмы хәл?* Ф.Яхин. *Язлык запас*

**2.** *и. мәгъ.* 1) Яз вакыты, язгы як, яз чоры. *Менә быел язлыкта гына Бибиҗамалга хаты килгән.* М.Мәһдиев. *Дөрес, ул үскән заманнарда хатын-кыз чалбар да, язлыкта кия торган чабата күтәрмәседәй биек табанлы туфли дә, менә бу кызныкыдай киң путалы, иңендә солдат погоны кебек калкып торган артык-портык нәрсәле аксыл плащ та кими иде.* Р.Кәрами

2) Яз өчен билгеләнгән нәрсә. *Кешеләр язлыкка дип чокырларга күмгән бәрәңгеләрен чыгаралар, төн йокламыйча, фонарь яндырып, сыер бозаулаганын, сарык бәрәнләгәнен саклап торалар.* Л.Ихсанова

3) Җәй көне яши торган, гадәттә шәһәр читендә урнашкан йорт, дача. *Быел атаклы хәрби очкычлар җиргә мәтәлеп төшеп, Мәскәү янындагы язлыкта яшәүче кешеләр һәм аларның йортлары зыян күрде.* Римзил Вәли. *Еллар үткәч, Зикурат – Обсерваториядәге ул язлыкны саттык.* Идел

**ЯЗЛЫ́К-КӨЗЛЕК** *с.* Яз һәм көз кия торган. *Кызга бер кат язлык-көзлек, кышлык-җәйлек өс-баш киемнәре, бизәнү әйберләре – ислемай, таракка кадәр!* Г.Сафиуллина

**ЯЗЛЫ́-КӨЗЛЕ** *рәв.* Язын һәм көзен. *Язлы-көзле машиналар, кереп, чирәмне изеп бетерә бит.* З.Мурсиев. *Баш очымнан очар язлы-көзле Кыр казлары, канат кагынып...* Л.Шагыйрьҗан

**ЯЗЛЫКТЫРУ** *ф. йөкл. юн. к.* **язлыгу**. *Шуңа да чем кара Чегән бия аны күзеннән беразга гына язлыктырса да, шундук борчыла, пошкыра, фырылдый башлый.* А.Хәлим. *Давылларны кичеп, язлыктырмый Тукай сөйгән биек йолдызны, Утлар йотып үткән кырларга да шәлкем чәчкә сибеп ул узды.* Кызыл таң

**ЯЗМА** *и.* **1.** 1) Нәрсәгә дә булса язылган сүзләр, кыска гына текст, язу. *Бу куен дәфтәренә күп еллардан бирле языла, анда башка төрле язмалар юк.* М.Мәһдиев. *Шул арада Күмеркүз капкадагы язманы укый башлады.* Р.Нуруллин

2) Берәр нәрсә турында язылган һәм гадәттә басылып чыккан мәкалә, әсәр һ.б. *Беренче сандагы язманы күрсәтүгезне үтенәм.* И.Юзеев. *Ул, һичшиксез, аның нинди язма икәнен беләдер.* Н.Гыйматдинова

3) Кулдан язылган, машинкада яки компьютерда җыелган язу; кульязма. *Әйе шул, Баязит абый: «Язмаларымны барлап, карап чыгарга вакытым җитми, хәлдән килгәнен тәмамлармын, синең өлешкә дә зур эш кала, Сәгыйть», – дигән иде.* А.Гыйләҗев. *Кемдәдер истәлекле язмалар, фоторәсемнәр, документлар бардыр, әти-бабайлардан калган язмалар сакланадыр.* Г.Мөхәммәтшин

4) Аудио, видео һ.б. форматта языла барган һәртөрле мәгълүмат. *Егерме икенче июнь төнендә синең вертолётның мәктәп тирәсендә очкан булырга тиеш, ул көнге язма исәнме?* А.Гыймадиев. *Телефонда тәүлек буена җыелган язмалар бихисап булып чыкты, автоответчиктагы хәбәрнең беренчесендә тимер тавышлы хатын-кызның катгый кисәтүе: «Шәһәр телефон станциясенә ундүрт сум бурычыгыз бар!»* К.Кәримов // Аудио, видео форматтагы иҗади әсәр. *Мин синең бөтен язмаларыңны тыңлап-барлап чыктым һәм шундый бер фикергә килдем. Синең репертуарда сагышлы җырлар да, шаяннары да җитәрлек.* Р.Батулла

**2.** *с. мәгъ.* 1) Язылган; язмача бирелгән; телдән генә булмаган. *Без, язучы халкы, күбрәк бүлмәдә, кабинетта утырып, халкыбызга язма сүз белән ярдәм итәргә тырыштык.* Н.Фәттах. *Моңа язма телнең якынлыгы, уртак гарәп графикасы да уңай йогынты ясаган.* Х.Миңнегулов

2) Языла торган; язып башкарыла торган. *Бу вакытта ук әле яшь кенә булган Фәезнең әдәбиятта, язма сүздә җиңелдән генә баручыларга карата бик тә принципиаль, килешмәүчән фикердә торуы хакында гомум сүз таралган иде инде.* Б.Рәхимова. *Халык авыз иҗаты язма әдәбият үсүенә нигез булган.* Р.Вәлиев

**ЯЗМЫШ** ы. 1) Тәкъдир; күрәчәк. *Ә мине ачы язмыш боларның барысы белән дә күзгә-күз очраштырды.* А.Мансуров. *Бәлкем, язмыш ялгышкандыр, Бәлкем, каргыш ябышкандыр безгә...* Б.Ибраһим

2) Нәрсәнең дә булса хәле, хәзерге торышы, үсеше-үзгәреше яки ни булып бетүе, азагы. *Ерак бабасы салдырган, Казанның архитектура һәйкәле саналган Әҗем мәчете язмышы турында көенеп мәкаләләр язды.* Г.Гомәр. *Күренекле дин галиме Муса Бигиев Коръәнне татарчага тәрҗемә иткән, дип сөйлиләр, ләкин, кызганычка каршы, бу кульъязманың язмышы турында берни дә билгеле түгел.* А.Тимергалин

3) Нәрсәнең дә булса алдагы көндәге яшәеше, киләчәге; киләчәктәге тормыш. *Кеше язмышлары, хәтта авылының үз язмышы хәл ителә торган сөйләшүләрнең берсе иде бу.* Г.Гыйльманов. *Җир шарының язмышы, киләчәк буыннар турында уйлау безнең баш миенә салынмаган.* Д.Гыйсметдин // Нәрсәнең дә булса алдагы хәле, яшәүяшәмәү, булу-булмау мәсьәләсе. *Хәзер китапның язмышы синең кулда.* Г.Галиева. *Озакламый мәҗлес тәмамлана, бәйрәмдарлар таралыша, ә ат бәһасе торган концерт гармунының язмышы хәл ителмичә кала.* Д.Гыйсметдин

◊ **Язмыш кочагына ташлау (ыргыту)** Берәр кешегә авыр хәлендә ярдәм итүдән баш тарту, кешенең хәленә кермәү. *Балаларын язмыш кочагына ташлап киткән ата-аналар, кызганычка каршы, бүген дә арабызда йөри.* Т.Нәҗмиев. *Ә Зөлфәт, туган җирен, әнисен ташлап, әле генә университетка кергән энесен язмыш кочагына ыргытып, авылдан китә аламы?* Р.Газиз

**ЯЗУ** I *ф.* 1) Нәрсәнең дә булса өстенә хәреф, цифр һ.б.ш. кебек билгеләр төшерү. *Һәм ул, акшарлаган нигезгә кызыл кирпеч белән тырнап, «Гәүһәр апа плюс Нургали абый тигез була дуслык» дип язды.* А.Тимергалин. *Озак уйлап тормады, алачыкка кереп, почмактагы соскыдан күмер алды да: «Без авылга кайтып киттек», – дип язды.* Г.Гыйльманов

2) Нинди дә булса язма текст төзү. *Ә Сәйдәшев, бер сүз дә әйтеп тормастан, туп-туры кадрлар бүлегенә китә һәм, эштән азат итүләрен сорап, гариза яза.* А.Тимергалин. *– Мин аңа барысын да аңлатып хат яздым инде, – диде кыз, артык борчылу күрсәтмичә.* А.Әхмәтгалиева

3) Берәр нәрсә турында язма рәвештә билгеле бер урынга хәбәр итү. *Мин сиңа абыйның өйләнүе турысында язган идем бит...* Г.Рәхим. *Урындагы*

*башбаштаклык турында үзәккә язу. Күршесе турында полициягә язу*

4) Берәр нәрсә турында матбугатта бастырып чыгару. *Газеталарда: «Без дошманга бер карыш җиребезне бирмәбез... Сугыш дошманның үз җирендә барачак!»* – дип язалар. А.Гыйләҗев. *– Гәҗит алып карыйк әле, нәрсә язалар икән? – диде ул һәм якында гына торган киоскка юнәлде.* З.Мәхмүди

5) Кемгә дә булса язма рәвештә мөрәҗәгать итү. *Аларның Үзәк Комитетка язып биргән дәгъва кәгазендә Мирсәет Солтангалиев корылтай делегатларына басым ясауда гаепләнә.* Р.Мөхәммәдиев. *Гаепләрен танып телләрен тешлисе урынга – жалоба язалар, әйтерсең мин гаепле.* З.Мурсиев

6) Нинди дә булса әсәр иҗат итү. *Көзге, кышкы озын кичләрне китап карап, китап язып үткәрергә ярата иде.* Гали Рәхим. *Мәсәлән, үзләре әйтүе буенча, И.Юзеев – утызлап, Ә.Рәшитов – унлап, Ф.Гыйззәтуллина дистәдән артык поэма язган.* Р.Фәйзуллин. *Бу көйне мин үзем яздым, анда мин бар!* А.Әхмәтгалиева

7) Башкарырга, үтәргә, эшләргә кирәк булган эшне язма рәвештә кушу. *Салып дәваламыйлар, дару язып кулыңа тоттыралар да, теләсә нишлә.* К.Кара

8) Исемлеккә кертү, теркәү; нинди дә булса оешмага, төркемгә әгъза итеп алу. *Киявем ишеткән дә: «Догаң кабул булды, әби, үзешчән түгәрәккә язабыз, тавышың әйбәт икән!» – дигән була...* Ш.Галиев. *Шулай да аны «Б» классына язганнар.* З.Мурсиев

9) Нәрсәне дә булса берәр кеше исеменә күчерү яки нәрсәне дә булса алу, бирү турында рәсми документ төзү. *Сарман ягыннан, Кәсле дигән глубинкадан өч йөз центнер солы симәнәсе язганнар.* А.Гыйләҗев. *Ә иң сөендергәне шул булды: тулай торактан берүзенә бер бүлмәгә ордер яздылар.* Д.Булатова

10) Бирелгән, кулланука тапшырылган һ.б.ш. нәрсә турында махсус карточка, дәфтәр кебекләрдә мәгълүмат теркәп кую. *Менә шул ике китапны алам, язып бирегез әле*

11) *дини* Насыйп булу, насыйп ителү, өлешкә төшү. *Туйда утыру безгә дә, сиңа да язмагандыр, әни...* И.Юзеев. *Шулай сиңа язган мал бар икән, ашыкма, ул үзе эзләп кулыңа керер.* А.Гадел

**Яза бару** Берсен дә калдырмыйча рәттән язу. *Бу дәфтәргә мин үземне кызыксындырган, икәвебез өчен дә кирәк булган барлык фикерләремне, уйларымны яза барачакмын.* Г.Кутуй. *Маруся апа, хәреф танырга яңа өйрәнгән бала сыман, иҗекләп, кабатлый-кабатлый яза бара.* Н.Әхмәдиев

**Яза калу** Берәр эш-гамәл башланганда әле язуын дәвам иткән булу; язу очрагы булу. *Аннары ул хат яза калды.* М.Хәбибуллин. *Әле шунысы да бар: уйлаганыңның барысын яза калсаң, каләмдәшләреңнең кәефе сүрелә, кайсыдыр хәтта рәнҗи, яный, куркаклары – качып, батырраклары күз алдыңда ук сиңа каршы начар гамәлләр кылырга тотына.* Р.Рахман

**Яза тору** Берәр эш-хәлгә кадәр яки аның барышында язу; әледән-әле язу. *Шулай итеп, ул үзенә күрә, үз дөньясы белән яши, ата-ана йорты хакында тыныч күңел белән уйлап куя, энесенең анда кайтуына сөенеп бетә алмый, болар хакында хатларында да яза торды.* Ф.Яхин

**Яза төшү** Тагын бераз язу. *Күләме тулып бетми, дигәч, тагын яза төштем*

**Язып алу** Тиз генә, тиз арада язу. *Яле, парин, исем-фамилияңне язып алыйк әле!* В.Нуруллин. *Әллә чыннан да, шушы ноктага карап, берәр повесть язып аласы инде.* З.Мурсиев

**Язып ату** Тиз-тиз генә, аннан-моннан гына яки ачу, кызулык, ялгышлык белән язу. *Куллары исән-сау булган Кәрим, мендәренә сөялеп утырган килеш, бу вакыйгага нигезендә фельетон язып атты.* З.Хөснияр. *Бу төнне җитди генә бер хикәя язып атыйм дип тотынган идем бит югыйсә.* Л.Ибраһим-Вәлиди

**Язып бару** Берсен дә калдырмыйча рәттән язу. *Старшина, үлгәннәрнең кесәләреннән документларын алып, исемлек язып барды.* З.Мурсиев. *– Давай, ал кәгазь-ручка, – диде ул, хәлне аңлап алгач, – тәртип белән генә язып бар: өйрәтәм хәзер кызлар белән ничек сөйләшергә икәнен.* А.Гыймадиев

**Язып бетерү** Язу эшен тәмамлау; барысын да язу; тәмам булганчы язу. *Бик күп авырлыклар кичердем, бик күп кыенлыкларны җиңеп чыктым, әмма ничек итсәм иттем – язып бетердем!* Г.Бәширов. *Аны язу минем иҗат планына керсә дә, төрле сәбәпләр белән, әле язып бетергәнем юк.* Ф.Сафин

**Язып бирү** Башка берәүләр өчен язу. *Бер брошюра язып бирдем.* Г.Бәширов. *– Язып бирегез сценарий, – диләр.* Т.Миңнуллин

**Язып җибәрү** Тиз арада язарга да өлгерү. *Кем әйтмешли, аппетит ашаганда килә: бер либретто тикле либреттом басылып чыкса, берәр композитор шуңа музыка да язып җибәрсә, мин мәңге тукталмаячак идем.* Ф.Яруллин

**Язып йөрү** Озак вакыт дәвамында язу; гел язу, даими язу. *Зөлфәтнең шигырьләрен ярата, Туфан, яшереп кенә, үзе дә шигырьләр язып йөргәндер, дип уйлыйм.* Ф.Яруллин. *Бу мәсьәләдә ул университетта диплом язып йөргән Нәркисне төп башына утырта ала.* М.Мәһдиев

**Язып калу** Язарга өлгерү; нинди-дер вакытка кадәр язу; моментыннан файдаланып язу. *Иң шәп шигырьләрен дә яшь чагында язып калды ул.* Р.Миңнуллин. *Онытылма, Риф Әлфинурович, магнитофоныңа язып кал.* К.Кәримов

**Язып килү** Күптәннән, әллә кайчаннан бирле даими язу. *Бу хакта мең еллар буенча язып киләләр, шәт, моннан соң да язудан туктамаслар.* Г.Бәширов. *Газетада мин үзем дөрес санаганны һәрдаим язып киләм.* И.Сираҗи

**Язып китү** Сүз уңаеннан язу; яза башлау. *Сүз уңаеннан язып китим әле: минем «Сиваш»ны әле һаман да яхшы китаплар рәтендә мактап телгә алалар.* Г.Бәширов. *Аннан соң Сибгать абый гадәтенчә хәрефләрен сирәкләп-сирәкләп язып киткән.* Г.Рәхим

**Язып кую** Язып әзер хәлгә китерү; алдан язу; тиз генә язу. *Бераздан, аңлатмага үзгәреш кертеп, «өч җиләк өзеп каптым» дигән сүзләр урынына: «Дүрт килограмм да биш йөз грамм җиләк ашадым», – дип язып куйдым.* Ф.Яхин. *Дәфтәрләргә бүгенге датаны һәм тикшереләчәк теманы язып куегыз.* Х.Ширмән

**Язып ташлау** *к.* **язып ату**. *Пионервожатый инде, межага утырып, район газетасы өчен мәкалә дә язып ташлый: «Башак җыялар» дип атала бу мәкалә.* М.Мәһдиев. *Ш.Маннур күмәкләшүдән соң язып ташлаган «Гайҗан бабай» кебек чат кызыл мәдхиянең (һәм аның дәвамының!) бу мәҗмугага да, шигырь антологияләренә дә керергә хакы юк, әлбәттә.* А.Тимергалин

**Язып тору** Даими язу; озак вакыт язу; сөйләү моментында яки әледән-әле язу. *Ташкенттан да хатлар язып тора абый.* К.Миңлебаев. *Ул көннәрдә мин Хәбир бабай әйткән саннарны, әйбер исемнәрен язып тордым.* В.Нуруллин

**Язып утыру** *сөйл. к.* **язып тору**. *Бу ысул – дәвахәнәдә дару язып утыру түгел, һәркемгә дә бер үк нәрсә ярамый.* З.Мурсиев

**Язып чыгу** Башыннан ахырына кадәр язу; язып бетерү; һәрберсенә бер-бер артлы язу. *Бер башлагач туктала алмадым: атна дигәндә, шундый ук бозлы-яңгырлы көзге кичтә, пьесаны яңадан язып чыктым...* А.Гыйләҗев

**Язып яту** *сөйл. к.* **язып тору**. *Нигә бүген, ул якларда яшәгән татар халкын читләтеп үтеп, өр-яңа тарих язып яталар соң, татарның бөек үткәне һәм бүгенгесе кемгә комачаулый?* Ф.Бәйрәмова. – *Ирек туган, – дип сүз башлады ул, – мин бер әйбер язып ятам.* Ф.Садриев

**ЯЗУ** II *и.* 1) Язганда кулланыла торган график билгеләр системасы; графика. *Киләчәк өчен әйтәм: рус графикасының кимчелекләре җитәрлек, шуңа күрә 50 нче еллар азагында аларда да латин язуына күчәргә кирәклеге турында җитди сүз кузгалган иде.* А.Тимергалин. *Шуңа күрә каршы стенада эленеп торган хәрби формага һәм аның янәшәсендәге гарәп язуына көннәр буе карап ятарга тиеш булды.* Г.Гыйльманов

2) Билгеле символлар системасын кулланып, мәгълүматны кәгазьгә төшерү яки башкача теркәү эше. *Язу эше бик күп*

3) Кая да булса, нәрсәгә дә булса язылган кыска гына текст. *Ишекләрендә берниндим язулар күрсәтелмәгән офиста, нинди дер пүнәтәйләр катнашында, Маратның һәм Әмирнең сумкаларын җентекләп тикшерделәр.* Д.Гыйсметдин. *Кәгазьләрдәге язулар Нәгыймгә кагылышлы иде шикелле, башын калкытып карап-карап ала иде аңа «кода».* К.Кара

4) Нинди дә булса текст язылган кәгазь. *Иң әүвәл парталар, андагы язулар, дәфтәрләр алынды, соңра һәммә кесәләр бушатылды, аннан кәгазьләр, хатирә дәфтәрләре җыелды.* Г.Ибраһимов. *Синең тар, кысан бүлмәң, төрле язулар, кәгазь-папкалар таралып яткан эш өстәлең һәм бик таныш кызыл телефон...* Р.Габделхакова

5) Берәр эш-хәл, аны үтәү турында рәсми документ. *Картлар йортына кирәкле язулар әзерләүләре дөрес булса, тиздән алып та китәрләр Хәнифә карчыкны.* Г.Исхакова. *Терелеп аякка баскач, армия, бер кочак акча белән гариплек язуы тоттырып, Ниязны үзе тәрбияләнгән ятимнәр йортына кайтарып җибәрә.* Г.Гыйльманов

6) Язарга өйрәнү дәресе. *Әткәй, әткәй, карале: мин матур язудан бишле алдым!* Ф.Абдуллин. *Укудан – биш, арифметикадан – биш, рәсемнән – биш, язудан – биш, тәртиптән – биш.* М.Мәһдиев

7) Кем дә булса язган хәрефләренең тышкы күренеше; язу рәвеше; кул, почерк. *Ләкин Мөнирә үзенең язуыннан бер дә канәгать түгел иде, аның язуы тәҗрибәле врачларның рецептлардагы вак бөдрәләренә бер дә охшамаган шул.* Г.Әпсәләмов. *Аның язуын йөз кешенеке арасыннан да танып алыр иде Мөхәммәт.* З.Хөснияр

8) Язучылык эше; язучы булу. *Язуга хирыслык әтидән күчкәндер.* Р.Вәлиев. *Чөнки ул инде укыганда ук үзенең язуга сәләтле булмавын аңлый башлаган иде.* З.Мәхмүди

**ЯЗУ** III *ф.* **1.** Кемне яки нәрсәне дә булса югалту, кемнән яки нәрсәдән мәхрүм калу. *Ләкин бу нәфрәтләнеп елау түгел иде. Кызлыгыннан язган кызлар елавы бу.* З.Мәхмүди. *Моның нәрсә икәнлеген өлкәннәр хәтерлидер: партбилетыннан язган кеше мотлак рәвештә эштән бушатыла, башкача ул гомердә дә җаваплы вазифага урнаша алмый.* З.Мурсиев. *Һуштан язу. Акылдан язу*

**2.** *ярд. ф.* Төп фигыльдән аңлашылган эш яки хәлнең аз гына булмый калуын аңлата. *Үзебезнең авыл кешеләренең һәркайсының холкын-гадәтен өйрәнеп бетә язган идем бит мин!* В.Нуруллин. *«Сыер дуласа, аттан яман» дигәндәй, мыштым гына агып яткан тау асты елгасы моңарчы да, су белән тулып ташыган чакларында, яр буендагы мунчаны, аннан бераз арырак утырган амбарларны агызып китә язган иде.* З.Хөснияр

**Яза бару** Торган саен ныграк язу. *Ул үзенең акрын гына акылдан яза баруын тойды...* Г.Гыйльманов

**Яза башлау** Язуга таба бару. *Әллә, бер бүлмәле квартир алдым дип, акылдан яза башладыңмы?* Р.Вәлиев

**Язып бару** *к.* **яза башлау**. *Әкрен генә акылдан язып барган кешелекне коткарыр көчнең кемдә, нәрсәдә икәнен аңламыйча, аңларга теләмичә, малга табынып яшәү күпкә җиңелрәктер шул...* А.Әхмәтгалиева

**Язып бетү** Тәмам язу. *Янында яткан капчыгының арыклыгы, үзенең таушалган саргылт йөзе, өметен югалта язып беткән тоник күзләре бу кешенең шатлыклы көннәрне аз күреп, нужамихнәт белән бик якын таныш икәнен белдерәләр.* З.Зәйнуллин. *Икесе дә, эчеп, юлдан язып беттеләр.* Р.Сәгъди

**ЯЗУ** IV *ф.* 1) Бөкләп, кысып, җыеп куелган нәрсәне турайту, ачу, җәю. *Тезләре өстендә яткан сөлгесен бер читкә алып куйды да, оеган аякларын язганда, ах-вах килеп, сәкедән төшә башлады.* М.Хәсәнов.

2) Хәрәкәтләндереп, кан әйләнешен тизләтү, хәрәкәтләрне җиңеләйтү, җайлау (очлыклар тур.). *Дөге өйрәсе ашап, кайнар чәй эчеп алгач, арыган буыннар язылгандай булды.* Г.Сабитов

3) Укмашкан, киезләнгән нәрсәнең һәр бөртеген аерым торырлык хәлгә китереп тетү, кул яки берәр әсбап белән тарткалап йомшарту. *Шушы сүзләрдән соң, Чыңгыз янына олы хатыны Бүртәне дә бастырып, ап-ак йоннан язган затлы киезне баш өстенә күтәрәләр.* А.Хәсәнов. *Үзебезнең сарыкның язгы йонын яздым, бик нечкә итеп җеп эрләдем.* М.Маликова

**Яза бару** Булган берен рәттән язу. *Йонны китерә баралар, яза барам.* Кызыл таң

**Яза тору** Берәр эш-хәлгә кадәр яки шуның барышында язу; әледән-әле, даими язу. – *Бераз аякларыгызны яза торыгыз, мин, өйгә кереп, капкалап чыгам, – диган ул.* Ф.Яруллин

**Яза төшү** Бераз язу; тагын да ныграк язу. *Мохтар абзый, җыерылган кашларын яза төшеп, Низамга карап куйды.* М.Хәсәнов. *Бераз утыргач, сыра куәте буыннарны яза төшкәч, Роза дигәне игътибарны Нияз белән Рәшиткә юнәлтте.* С.Зыялы

**Язып бетерү** Барысын да язу; язу эшен тәмам итү. *Язып бетерүгә, йоннарны алып китә баралар*

**Язып бирү** Башка бирәү өчен язу. *Йон язып бирү*

**Язып җибәрү** Бераз язу. *Бу юлы Илбариска озак азапланырга туры килмәде: ул ике-өч талпынуда өскә шуып чыкты, чалкан яткан килеш аякларын сузып, тәнен язып җибәрде, аннары гына баягы мәче ягына борылып карады.* Г.Гыйльманов. *Интегәсе дә түгел, тырышасы да. Нибары бармакларны гына язып җибәрәсе.* Д.Булатова

**Язып тору** Даими яки әледән-әле язу; әле, хәзерге вакытта язу. *Без килеп кергәндә, әби йон язып тора иде.* Ялкын

**ЯЗУ** V *ф.* 1) Май ясау өчен каймакны туглау; атлау. *Кунак апалар гөбедә*

*май язалар, ә майлары төшми.* Г.Әпсәләмов. *Ә хатыннар ак май язар, Сөт өстеннән әйрән сыгар – Ап-ак икмәк, кымыз чыгар!..* Л.Шәех

2) *сөйл. сир.* Гомумән нәрсәнедер болгату, туглау. *Телефоннан акырышып эш чыкмас, су язып май төшми!* А.Гыйләҗев

**Яза тору** Берәр эш-хәлгә кадәр яки шуның барышында язу; әледән-әле, даими язу; берәр вакытка кадәр язу. *Хафиз карт ишегалдында бәрәннәрне эш иткән арада, мин, гөбегә салып, шул каймактан май яза тордым.* В.Нуруллин

**Язып бетерү** Язу эшен тәмамлау; тулысынча язу. *Май язып бетергәч чыгам*

**Язып бирү** Башка берәү өчен язу. *Әнием белән бертуган апам, кәҗә сөтләрен җыеп, миңа бер кадак май язып бирде.* Ф.Яруллин

**Язып тору** Сөйләү моментында яки әледән-әле язу. – *Сөтне, каймакны әрәм итмибез инде, атнага бер май язып торам, – ди Нурия апа.* Кызыл таң

**ЯЗУЛЫ** *с.* Язуы булган, нindидер тексты булган. *Гарәфи абзый, алтын язулы папиросны бармак очларында әйләндерә-әйләндерә, киез эшләпәле башын кыйшайтып, Газинурга текәлде.* Г.Әпсәләмов. *Адреслар да алмашканнар иде, язмыштыр инде: ул язулы кәгазьне Казан вокзалында очраган иң беренче патруль алып калды.* Г.Гыйльманов

**ЯЗУ́-СЫЗУ** *җый. и.* Язу II (*2 мәгъ.*) эше. *Фатих бай никадәр эшкә кушарга теләсә дә, бердән, язу-сызу белмәве, бердән, ышанычсызлыгы өчен, кибеткә дә чыгармыйлар иде.* Г.Исхакый. *Гыйлемлегe, язу-сызу осталыгы булмый диярлек үзенең, әмма сөйләшергә, сатулашырга, кирәкле әйберне җир тишегеннән булса да табып алып кайтырга маһир була.* Т.Нәҗмиев

**ЯЗУЧЫ** *и.* Әдәби әсәрләр яза торган кеше; әдип. *Әдәбият – әдәп тәрбияләү, дигәнне онытмаска һәрбер язучының... хакы да, бурычы да бар.* Б.Рәхимова. *Язучы милли аңлы, тирән белемле һәм горур булырга тиеш. Халык нәкъ менә укымышлыларына зур өмет белән карый һәм алардан милләтне баткаклыктан сөйрәп алып чыгудан башлап йөрүне көтә.* Т.Әйди

**ЯЗУЧЫЛЫК** *и.* Әдәби әсәрләр язу эшчәнлеге; язучы хезмәте. *Кулына яңа гына каләм алган яшьләргә ул язучылык эшенең гаять зур белем, эрудиция таләп иткәнлеген һәрвакыт әйтә килде.* М.Мәһдиев. *Бүгенге көндә гомерен язучылык эшенә, әдәбиятка багышларга алынган кеше – фидакяр зат ул.* Р.Фәйзуллин

**ЯЗ ЧӘЧКӘСЕ** *и. бот., диал.* Күкебаш; *русчасы:* **медуница**. *Сарымсак чәчәге һәм күкебаш (яз чәчкәсе) җыеп кайттык*

**ЯЗЫК** *и. дини* Гөнаһ. *Җир башына килеп җиткәч, күңел әйтә: «Кеше өлешенә кермә, Галимҗан, яхшы түгел, язык була», – ди.* Г.Бәширов. *Кара аны, кызый актыгы, хәзер дә сак була бел: минутлык вәсвәсәгә бирелеп, өстеңә язык алма.* А.Гыйләҗев

**ЯЗЫКЛЫ** с. *дини* Гөнаһлы. – *Языклы бәндәләреңнең күңеленә дә шәфкать чаткысы, миһербанлык иңдер! – дип кабатлады Сөмбеләнең шиңгән чәчкә төсле иреннәре.* А.Гыйләҗев. *«Урлаган бер языклы, урлаткан мең языклы» дияргә ярата ул, хатыныннан качып безгә әче бал эчәргә кергәч.* З.Хөснияр

**ЯЗЫЛУ** I *ф.* 1) *төш. юн. к.* **язу** I. *Аларда авылда мәчет төзергә һәм мәктәп-мәдрәсә ачарга киңәшләр бирелгән, кирәк булса, матди ярдәм күрсәтәчәкләре турында язылган иде, рәхмәт төшкере.* А.Хәлим. *Ә анда «Хәдичә, гөлкәем, сине чишмә юлында көтәм» дип язылган иде.* А.Мансуров

2) Берәр оешмага, коллективка әгъза булып керү, шунда теркәлү. *Шунда мин тоттым да Кызыл Армиягә үзем теләп язылдым.* А.Шамов. *«Мөхәммәдия» мәдрәсәсен кат-кат мисал итеп китергәнем бар үзегезгә, исегезгә генә төшерәм: шәкертләр оештырган әдәбият түгәрәгенә язылган кеше, түгәрәккә килгәндә, һәрчак яңа язмасын алып килергә тиеш булган.* А.Әхмәтгалиева

3) Алдан хак түләп, билгеле бер вакыт дәвамында газета-журнал һ.б.ш.ны китерүне рәсмиләштерү. *Бөтенләй юк дигәндә дә, бер-ике исемдәге булса да, матбугатка язылырга акча таба ала ул безнең халык.* Б.Рәхимова. *Бик теләгәндә дә, языла алсалар, бер яки ике газета-журналга язылалар.* Р.Фәйзуллин

4) Социаль челтәрләрдә билгеле бер аккаунт, сайт һ.б.ш.дан килгән хәбәрләрне кабул итәргә, даими карап барырга ризалык белдерү. *Ни кызганыч, Русиядәге канкойгыч вакыйгаларны тудыручы яшьләр дә мәктәп сугышлары турындагы Тру крайм комьюнити пабликларына, блок һәм сайтларына язылган булган.* Кызыл таң. *Бу акциядә катнашу өчен, министрлыкның Instagram челтәрендәге аккаунтына язылган булу шарт.* Мәйдан

5) *к.* **язылышу**. *Берсе алганлык, икенчесе барганлык хакында язылырга калдылар.* Г.Камал

**Языла бару** Әзлекле рәвештә язылу. *Дөрес, әңгәмәгез магнитофон тасмасына языла барыр, ләкин сезне берәү дә тыңлап тормас...* А.Тимергалин. *Сүзләре күңелемә уелып языла бардылар.* Ф.Яхин

**Языла башлау** Язылырга тотыну. *Көнен-төнен өстәл артында утыра, языла башлаган хезмәтен тәмамларга ашыга.* Р.Мөхәммәдиев. *Мин, Земфирага дип языла башлаган хатны кулыма алып, озак еладым.* Я.Шәфыйков

**Язылып йөрү** Язылуга озак вакыт сарыф итү; күптәннән бирле язылу, шактый вакыт язылу. *Почтага барып язылып йөрү – үзе бер мәшәкать, ә монда почта хезмәткәрләре дә бар, сорауларың булса, журналистлар да шушында гына.* Шәһри Казан

**Язылып калу** Язылырга өлгерү; нindидер вакытка кадәр язылу; моментыннан файдаланып язылу. *Шуңа күрә журналга сентябрь-октябрь айларында язылып калу хәерлерәк.* Казан утлары

**Язылып кую** Алдан язылу. *Күпме белемле кеше кибетләрдән яхшы китап эзли, күптомлы басмаларга берәр ел алдан язылып куя, таныш-белеш аша берәр дефицит китап юнәтсә, төлке тоткан кебек сөенә.* Р.Фәйзуллин. *Бару белән «Казан утлары» журналына, «Социалистик Татарстан» газетасына язылып куйган идем.* М.Вәлиев

**ЯЗЫЛУ** II *ф. төш. юн. к.* **язу** IV. *Корсагы бераз кимегәч, буыннары язылгач, бөтен көченә куалый башларга булыр.* В.Гали. *Ул, оешкан буыннар язылмасмы дип, берара койма буйлап арлы-бирле йөренде.* Ф.Абдуллин

**Языла бару** Торган саен күбрәк язылу. *Йөргән саен аяклар языла бара*

**Языла башлау** Язылуга табан бару. *Картларның үзләренең дә буыннары языла башлады шикелле, йөзләренә өн чыкты.* Х.Камалов. *Аяклары языла башлады, башы артка китте, иреннәре әкрен генә ачылып, тешләр ыржайды, ике теш казнасы телен кысты.* Р.Батулла

**Языла төшү** Бераз язылу; тагын да язылу. *Фазулланың зәңгәрсу төскә кергән озын бармаклары гармун телләре өстендә уйнаклый башлауга, бөкресе языла төшеп, гәүдәсе тураеп киткән кебек күренде.* Г.Бәширов. *Елмаюдан маңгай җыерчыклары да языла төшкән бит!* Г.Әдһәмова

**Язылып бетү** Барысы да язылу; тулысынча язылу. *Күптән инде бизәнүне оныткан йөз, артык ябыклыктан зураеп калган сыман куллар, авырудан язылып бетмәгән авыр гәүдә – болар барысы да хатынның сөйкемлелегенә каршы аргументлар иде.* Л.Ибраһим-Вәлиди

**Язылып җитү** Тиешле дәрәҗәдә язылу; бераз язылу. *– Аяк язылып җитми, иптәш военврач, – диде Нәгыймов, хәлсез генә йөзен җыерып.* Х.Камалов

**Язылып китү** Билгеле бер моменттан алып язылу. *Артык кысташмыйча берәр бокал шәраб җибәргәч, ничектер уйлар ачылып, буыннар язылып китте.* Х.Ибраһим

**ЯЗЫЛУЧЫ** *и.* 1) Вакытлы матбугатка язылган кеше; газета-журналлар алдыручы; абунәче, мөштәри. *Яртыеллык ахырында бер генә язылучы кимегәнен күрсәң дә, үз-үзеңне ашарга ябышасың: нишләп газетага язылмадылар икән, булдыра алганча тырыштым, язмаларыма бар җан җылымны салдым, ачынып хат язганнарга көчемнән килгәнчә ярдәм итәргә тырыштым бит, дисең.* И.Фәйзрахманов

2) Социаль челтәрдә билгеле бер аккаунтны һ.б.ш.ны карап баручы кеше. *Сәхнә мәтрларына килгәндә, Салават Фәтхетдиновның битендә йөз ике мең язылучы бар.* Идел. *Социаль челтәрләрдәге сәхифәләремдә 50 меңләп язылучым бар.* Шәһри Казан

**ЯЗЫЛЫШ** *и.* Язылу (I) рәвеше, язылу (I) үзенчәлеге. *Алар шигырьнең төзелешенә, аның язылыш техникасына, формасы-калыбына бөтенләй игътибар итмиләр диярлек.* М.Шабаев. *Мине «Ана теле» исемле мәкаләдә тикшерелгән төрле-төрле сүзләрнең һәм гыйбарәләрнең кайсы телдән кайсы телгә килеп керүе, аларның кулланылыш даирәсе, потенциалы һәм язылыш үзенчәлекләре кызыксындыра.* А.Тимергалин

**ЯЗЫЛЫШУ** *ф.* Өйләнешүне рәсмиләштерү. *Язылышуын гына язылыш, паспортыңда мөһере генә булсын, туй ясамагансыз дип, кире аера торган гадәт юк.* Н.Әхмәдиев. *Беренче мәшәкать күңелле иде – яңа гына институт тәмамлаган олы кызы, Казаннан кияве ияртеп кайтты да: «Без язылыштык – өйләнештек», – диде.* Р.Габделхакова

**Язылышып җибәрү** Тиз генә язылышу. «*Язылышып җибәрик әйдә*», *– димәсенме шулчак егет.* М.Вәлиев

**Язылышып калу** Язылышырга өлгерү. *– Син киткәнче язылышып калырга кирәк безгә, – диде ул кыю гына.* Сөембикә

**Язылышып кую** Алдан ук язылышу. *Тәкый абзыйның яшьләрнең, картлар киңәшен тотмыйча, астыртын гына язылышып куюларына бик җене каткан икән.* Р.Төхфәтуллин. *Ул – хәрби кеше, кунакка гына кайткан иде. – Без язылышып куйыйк, – диде.* Ф.Яруллин

**ЯЗЫН** *рәв.* Яз көне, яз фасылында. *Язын күмәкләшеп чәчү чәчәбез дә көзе белән бергә җыячакбыз, уртак бүләчәкбез...* В.Имамов. *Менә ничә еллар инде күктән күземне алмый, язын, җәен – яңгыр, көзен болытларның таралганын көтеп яшим.* Д.Салихов

**ЯЗЫ́Н-КӨЗЕН** *рәв.* Яз һәм көз айларында; яз яки көз булуга карамастан. *Хастаханә тирәләрендә һәрвакыт, җәен-кышын, язын-көзен, үзенә бертөрле әчкелтем-төчкелтем ис була.* Г.Әпсәләмов. *Кышын кар баскан тар сукмактан йөреп җәфалансаң, язын-көзен пычракны ерып чыкмаслык баткак була.* Г.Әдһәмова

**ЯЗЫНУ** *ф. сир.* Бераз язу эше белән шөгыльләнү. *Үзе укый белмәсә дә, гомер буе язына.* Табышмак. *Иртәгә ерактагы бер шәһәргә китәсе кичендә ул, безнең бүлмәгә кереп, шактый озак язынып утырды.* М.Әмир

**ЯЗЫШУ** *ф.* 1) урт. юн. *к.* **язу** I. Кемгәдер нәрсәдер язарга ярдәм итү. *Инша язышты*

2) Бер-берәңә хат язу; хат аша хәбәрләшеп тору. *Әгәр хаттагы даталар дөрес булса, болар дүрт елга якын язышкан.* А.Гыймадиев. *Аның белән хат язышканнан соң әйбәтләнеп китте минем тормышым!* Г.Гыйльманов

3) Матбугатка мәкалә-очерклар язгалап тору. *Ул 1915 еллардан «Ак юл», «Аң» журналларына актив языша, шигырь-поэмалары бер-бер артлы басылып кына тора.* М.Шабаев. *Син – көндәлек (вакытлы дип тә әйтәләр) матбугатта иң актив язышкан әдип.* Р.Фәйзуллин

**Языша башлау** Язышырга тотыну. *Әнәс ага өлкән яшьтә иде инде, без языша башладык, җитмешенче еллар...* М.Мәһдиев

**Язышып килү** Эзлекле рәвештә, күптәннән язышу. *Нәтиҗәдә газета-журналның ни икәнен белмәгән авыл хатын-кызлары хәзерге көндә «Азат хатын»ны укып бару гына түгел, аның битләренә язышып киләләр.* Һ.Такташ

**Язышып тору** Озак вакыт дәвамында даими язышу; әле, хәзерге вакытта язышу. *Сигезенчедә, тугызынчы, унынчыда укыганда да хат язышып тордык Илдар абый белән.* Л.Фаршатова

**Я́ИСӘ** *терк.* 1) Тиңдәш кисәкләрне яки тиңдәш җөмләләрне теркәп, аларга санау, сайлау төсмере өсти. *Хуҗамның улы Фәрһад, укудан яисә хоккей уйнаудан буш чагында, әллә нигә бер булса да, мине урамга, саф һава суларга алып чыга.* А.Хәсәнов. *Бердәүләр Алланың барлыгына чын күңелдән ышанса, икенчеләре Аңа өлешчә генә ышана яисә бөтенләй ышанмый.* З.Мәхмүди

2) Санап киткән тиңдәш кисәкләрнең соңгысын башкаларына каршы куя: әллә, бәлки. *Я орчыктай бөтерелеп ала, я бер урында туктап кала яисә бөтенләй каядыр агып китә...* Г.Гомәр. *«Я бу адәм Наиләне бөтенләй яратмый, яисә, яратса да, көнләшү дигән нәрсәнең ни икәнен дә белми торгандыр», – дип уйлаган иде Фәләх, аның шулхәтле түзем булуына исе китеп.* В.Нуруллин

3) Әйтелгән фикерне ачыклый яки аңа нәрсә дә булса өсти, конкретлаштыра торган сүз яки җөмләне берләштерү, теркәү өчен кулланыла. *Ләкин аның куллары кочмыйлар мине, яраткан ир-ат куллары түгел бу, бөтенләй икенче, әйтерсең яраткан абыйсы сеңлесен үз итеп сыендыра, яисә ана баласын иркәләгән төсле.* К.Кара. *Мондый төпләр күп булса – димәк, утынга кисканнәр. Яисә йорт-кура өчен...* Г.Гыйльманов

**ЯК** I *и.* 1) Нинди дә булса бер юнәлеш, тараф. *Шул тавышны алып киткән җил көзгедәй күлнең өстен урман ягына таба йөгергән нәни дулкыннар белән шадралата.* А.Алиш. *Мансур, күз ачып йомганчы, көйләне тавыш ишетелгән якка таба борды.* Г.Әпсәләмов

2) Урталыктан читтә булган, ян тарафтагы урын; кемнең яки нәрсәнең дә булса уңында яки сулында урнашкан урын. *Уң як күршедәге бик матур йортта яшәүче Гәүһәршад исемле хатын мәрхүм ире зәргәр Биктимер көмештән койган кәмәр каптырмалары бүләк итте.* А.Тимергалин. *Керүгә сул яктагы стенага күз явын алырлык матур чәчәкле келәм эленгән.* В.Нуруллин

3) Елга, урам, юл кебек буйга сузылган нәрсәләрнең ян ягындагы, кырыендагы урын; оч. *Поезд бер башыннан йөгереп керә дә икенче башыннан йөгереп чыга, шулчак инде ул елганың аргы ягына чыгып та җиткән була.* А.Алиш. *Биш-алты йөз йортлы Чыр-*

*шыбаш исемле бу авыл инешнең калкурак уң як ярына утырган.* Д.Булатова

4) *Уң, сул, тискәре* һ.б.ш. сүзләр белән килгәндә, берәр предметның, әйбернең (мәсәлән, тукыманың) кайсы да булса өслегеН белдерә. *Чалбарын салып урындык артына элгән, ярымшәрә килеш идән уртасында басып тора, кулында халаты, тырыша-тырыша, ул аның уң ягын әйләндереп маташа.* З.Хөснияр. *Күлмәген тискәре яктан кияр иде. Байыйм, дип.* Н.Гыйматдинова

5) Нинди дә булса бинаның аерым өлеше яки бүлмәсе. *Миңнехан йокыдан торып алгы якка чыкканда, Зөбәйдә өстәлгә алсуланып пешкән гөбәдия куйган иде инде.* В.Имамов. *Мунчадан кайткан җиргә безне түр якта бай итеп әзерләнгән өстәл көтә иде.* А.Нәҗми

6) *мат.* Геометрик җисем хасил иткән ян яссылыкларның һәрберсе. *Өчпочмакның һәр ягы Бер шырпы буе булсын.* Р.Нуруллин

7) *мат.* Геометрик фигураны хасил иткән сызыкларның һәрберсе. *Квадратның бер ягы 10 см булса, турыпочмаклыкның иңе ничә см була?* Сабантуй

8) Нинди дә булса бер өлкә, төбәк; ил. *Урманнар киселә, сулыклар, һава пычрана, туган як табигате елдан-ел ярлылана бара.* А.Хәсәнов. *Актаныш ягы – гүзәл табигатьле, җырлы-моңлы як.* Л.Җамалетдинов

9) Бер-берсенә капма-каршы булган ике кеше тормышы, күренеш, предмет һ.б.ш.ның берсе; тараф. *Бер якта – куштаннар һәм кулаклар, икенче якта – халыкның калганы иде.* М.Галәү. *Көчләр тигез түгел: бер якта – мәхәббәткә сусаган таза-йомры авыл егетләре, икенче якта – шәхси милекне, ягъни алма, алмагачларны, каралтыкураны һәм, әлбәттә, яраткан оныгын көтеп, саклап постта торучы сугыш инвалиды.* Д.Гыйсметдин

10) Нинди дә булса эш, мөнәсәбәт буенча бер-берсенә каршы куелган кешеләр яки кешеләр төркеме. *Рәшит Нәҗметдиновның бу искиткеч партиясендә дошман як бердәнбер хата җибәрә.* А.Тимергалин. *Озын-озак бәхәсләрдән соң, ниһаять, ике якны азмыкүпме канәгатьләндерә алырлык уртак килешүгә ирештеләр.* Р.Вәли

11) *юр.* Судта гражданнар арасындагы низаг, бәхәс һәм җинаять эшләре хәл ителү барышында бер-берсенә каршы булган кешеләр; гаепләүче яки гаепләнүче. *Әгәр яклар үзара килешсә һәм китерелгән зыян тулысынча түләнсә, чыннан да, авыр булмаган җинаять эшләүчегә карата ачылган җинаять эше туктатылырга да мөмкин.* Шәһри Казан. *Зыян күрүче як*

12) *сөйл.* Нәсел, кардәшлек кемгә карата билгеләнү, кемгә бәйле булудан чыгып күрсәтелгән тараф турында. *Синең кызны кичереп тә була, кыз барыбер инде – ир ягы.* Р.Мингалим. *Шул бәягә төшереп узган туй мәҗлесеннән соң бүләкнең ниндилеген ике яктан да (ир белән хатын ягы) тикшерү китә.* Безнең гәҗит. *Әти ягы. Әни ягы*

13) Кемне яки нәрсәне дә булса билгели, характерлый торган берәр сыйфат, үзенчәлек. *Акылың булса, күп фәлсәфә сатма, кыланма, лучше, ике күзеңне дүрт итеп, иптәшләреңә бак: яхшы якларын үзеңә күчер, начар якларын кабатлама.* Г.Әпсәләмов. *Кеше холыкфигылендә, бер тора торгач, андый яклар да калкып куя икән ул.* А.Хәсәнов

14) Нинди дә булса мәсьәләнең бер аспекты, бер нигезе. *Юридик яктан проблема юк, атарга лицензия бирелгән дип исәплә.* Ә.Әминев. *Матди яктан аякка басып, үги әнкәсенә вакытвакыт ярдәм дә иткәли башлагач, инде бик картайган немец карчыгы да Азатка гаилә кору турында киңәш биргән һәм нәкъ минем дәлилләрне китергән икән...* А.Тимергалин

**ЯК** II *и. тибет. зоол.* Куышмөгезлеләр семьялыгыннан Үзәк Азиянең таулы өлкәләрендә сөт, ит һ.б. алу һәм эш терлеге итеп файдалану өчен асрала торган күшәүче эре хайван. *Як – эре, көчле һәм чыдамлы хайван.* География. *Кыргый яклар турында Тибет елъязмаларында мәгълүмат бик күп.* Ялкын

**ЯКА** *и.* 1) Киемнең муен өчен калдырыла торган уем һәм шул уемга тегелеп куелган тукыма кисәгеннән гыйбарәт детале. *Мин яңа күлмәк тектем, Курчакка бүләк иттем. Түгәрәк яка уйдым, Ап-ак күбәләк куйдым.* Р.Вәлиева. *Гөлтуташ иске күлмәгеннән, чамалап, җиң, яка өлешләрен кисеп ала, Зифа, бармак битләрен йөз кат тишкәли-тишкәли, итәк асларын бөрә-бөрә тегә.* В.Имамов

2) Аерылып, күренеп торырлык итеп, тукыма, челтәр һ.б.ш.дан эшләнеп, киемнең муен уемына тышкы яктан тегеп, төймәләп яки беркетеп куела торган өстәмә материал. *Аның өстендә күн якалы зәңгәр сырма, яшел бумази чалбарының балакларын лыпылдатып, кыска ботылар киеп куйган.* М.Мәһдиев. *Челтәр яка үргән көннәр истә, Кичләр буе бизәк сипләгән...* Г.Айзат

3) Өске киемнең муен уемы тирәсенә беркетеп яки тегеп куела торган мех. *Тамагымны саклар өчен, авыз-борынымны мех яка эченнән бер дә чыгармыйм.* Ә.Еники. *Теге хатын көмеш сыман төлке яка алган.* Х.Камалов

4) *күч.* Якын урын; ян, кырый, чит; яга. *Инәйне, юрганын ачып, кабер якасына куйгач, энем белән миңа кабергә төшәргә куштылар...* Ә.Еники. *«Бар, бар!» – дип, эчтән ниндидер көч әйди аны, һәм ул, китмәкче булып, чокыр якасына үрмәләп менә, ләкин пулярларның җанөзгеч выжылдавы тагы аска таба тартып төшерә.* Х.Камалов

5) *күч.* Су, елга, тау һ.б.ш.ның буеннан-буена сузылган өлеше; буй. *Ул чагында әле ярның бу яктагы якасында безгә каршы өч-дүрт йорт булып, аларның һәркайсы, чокырга ачуланган-дай, сырты белән утырган, тәмам йөз чөергән иде.* К.Миңлебаев. *Яка термины татар ономастикасында (барлык төр ялгызлык исемнәрен өйрәнә торган фәндә) елга яры, тау кырыйларын аңлата, күчерелмә мәгънәдә кулланыла.* Ф.Гарипова

◊ **Яка астына (артына) салу** Исерткеч эчемлек эчү; кәгү. *Әтиләр күрмәгәндә яка астына салдык берне.* М.Вәлиев. **Яка астына (артына) төшерү** *к.* **яка астына (артына) салу**. **Якага яка килү** Ызгышу, талашу, кыйнашу; ярсып сугышу. *Тик шунысы яман: кергәннәр дә, янә татарлыклары кузгалып, бер-берсенә нәҗес сүзләр әйтешә башлаганнар, якага яка килгәннәр, әдәпсезләнеп беткәннәр, дөмбәсләшкәндә тәһарәтләре бозылган.* А.Тимергалин. *Үз гомерләрендә бер-берсе белән беренче кат якага яка килгәнгә уңайсызланыпмы, көчләренең тигез икәнлеген белгәнгәме, кичәге җан дуслар сугышмадылар.* Ә.Гаффар. **Якадан алышу** *к.* **якага яка килү**. *Я булмаса баштан ук якадан алыша, чәкәләшә башлыйлар.* М.Хафизов. *Әле теге, унике хуҗалык белән районда беренче булып колхоз төзегән елда ук, алар, соңыннан кан дошманнарга әверелерлек булып, якадан алышканнар.* В.Имамов. **Якасына ябышу** *к.* **якасыннан алу**. *Аларның кулына сугучы, якасына ябышучы якын араларда, ихтимал, булмас та.* Н.Шәрифуллин. **Якасыннан алу** 1) Берәр нәрсә таләп итү, нидер эшләргә яки сүз, сер әйтергә тупас

рәвештә мәҗбүр итү; көч куллану. *Кемдер бер генә кирегә сукалый торган сүз әйтсә, тегенең якасыннан алуга ук барып җитәргә мөмкин.* М.Хәсәнов. – *Нигә, Мулланур, минем малайны якасыннан алдың? – дип, шофёрның әнисе чәчрәп чыга.* М.Яһудин; 2) Авыр, котылгысыз хәлгә кую. *Бервакыт үз малың үзеңнең якаңнан алыр, димәдемме [сиңа]?* Г.Ибраһимов. *Үлем якаңнан алгач та килене белән сатулашып ятма инде, әти кеше!* Р.Сибат; 3) Зур куркыныч астына кую, янау. *Грипп якаңнан алмасың дисәң, мондый ысул бик отышлы: ике лимонны һәм ике тырнак сарымсакны угычта уарга да, барлыкка килгән боткага бер литр кайнаган су агызырга.* Татарстан яшьләре. *Акчаңны учлап, дару эзләп йөгергәнче (ярый ла йөгерә алсаң яисә янәшәңдә ярдәм итүчең булса), авыру чын-чынлап якаңнан алуы бар.* Туган як; 4) Үзеңә буйсындыру; үзеңчә эшләтү. *Язмышның якасыннан алып, этләнеп-үҗәтләнеп яшәргә күптән вакыт.* В.Имамов. *Әлегә безнең яшәештә «Мәскәү якаңнан алса» дигән гыйбарә ешрак яңгырый.* Кызыл таң. **Якасыннан тоту** *к.* **якасыннан алу**. *Үлем ястыгына аугач, әҗәле якасыннан тоткач, ул аңлады ки: гап-гади бер нәрсәгә аның җавабы юк икән ләбаса.* Р.Батулла

**ЯКАДАШ** *и. окказ.* Якалашучыларның берсе. *Катлы-катлы итеп, пристань хуҗаларын сүгүчеләр дә бар, эч пошканнан, кан оешканнан берәрсе белән якалашып алырга якадаш, кулдаш, билдәш эзләп йөрүчеләр дә юк түгел.* А.Хәсәнов

**ЯКАЛАШУ** *ф.* 1) Даулашу, талашу; сугышу. *Хәлфә мәдрәсә турысына килеп җиткәндә, әле генә шау-гөр килеп якалашкан, кычкырышкан малайлар, бик әдәпле, тәти малайлар кыяфәтенә кереп, песием генә булып калалар.* Г.Бәширов. *Нәкъ шул мизгелдә ишектән бәрелә-сугыла Сәет килеп керде һәм якалашыр дәрәҗәгә җитеп кызган яу башлыкларының бәхәсен өзде.* В.Имамов

2) *күч.* Көрәшү; бирешмәскә тырышу; нинди дә булса авыр шартлардан, янаган куркынычтан котылырга тырышу. *Сугыш алдыннан шушы тыптыныч, кешеләре әйбәт авылда, ялгыш сүз ычкындырмагаем дип, дер калтырап яшәдек, сугышта Газраил белән якалаштык.* М.Хуҗин. *Ике тәүлек буе Ак бабай үлем белән якалашты.* Г.Гыйльманов

**Якалаша башлау** Якалашырга тотыну. *Минем хәл дә әйбәттән түгел иде: көпә-көндез, айнык баштан, урам уртасында дигәндәй, якалаша башла, имеш!* Ш.Маннур. *Кайсы кушаматы белән дәшсәләр дә, ул ялт борыла, дәшүчегә акаеп карый, шундук тибешә, якалаша башларга да күп сорамый.* Ф.Садриев

**Якалаша язу** Чак кына якалашмый калу. *Алар хәтта якалаша яздылар, ярый әле Заһидулланың әтисе Гыйбадулла карт сабыр акыллы кеше иде, икесен ике уңайга салып аерды ул аларны, юкса бит Габдрахман: – Раскулачабайт итәм мин сине! – дип тотынган иде.* Р.Сибат. *Шәйхенуров белән якалаша яздык.* Ю.Әминев

**Якалашып алу** Тиз генә, аз гына якалашу. *Шул рәвешле атлар өчен шактый гына якалашып алгач, Фәтхерахман карт тына.* В.Имамов

**Якалашып бетү** Якалашуга барып җитү; бик нык якалашу. *Сезгә акча бирсәк, якалашып бетәр идегез бугай.* Безнең гәҗит

**Якалашып йөрү** Төрле вакытта, төрле җирдә якалашу. *Теләсә кем белән якалашып йөрергә Гайдулла Кәнделеме әллә син!* М.Хәбибуллин

**Якалашып карау** Якалашырга тырышу. *Җылы ташпулатларга кереп оялаган, үз җирендә, үз иленда һәр таш, һәр агач, һәр инеш ярдәм иткән басурман дошман белән якалашып кара!* Ф.Латыйфи. *Бар син, якалашып кара Гыйрфан мулла белән, җаныңны суырып алып, уч төбеңә китереп салыр.* С.Поварисов

**Якалашып китү**Ниндидер сәбәптән кинәт якалашу. *Татулануга ничә ел тулуны бәйрәм итәргә дип очрашкач, мактанышып тост әйтешкәндә якалашып киткәннәр.* Ш.Галиев. *Алар якалашып киттеләр, аннары бугазга-бугаз ябыштылар.* А.Хәсәнов

**Якалашып тору** Даими якалашу; сөйләү моментында якалашу. *Әлеге матурлык белән фаҗига фәрештәсе сугышып яшәгән кебек, шатлык белән кайгы да һәрвакыт якалашып торадыр ул.* С.Поварисов

**ЯКАЛЫ** *с.* Якасы булган; яка тегелгән, яка утыртылган. *Аларның өсләрендә, кайткан саен, җемелдәп торган яхшы якалы затлы пальто, биек каракүл бүрек була.* Г.Бәширов. *Өстендә зәңгәр чәчәкле ак якалы яңа күлмәк, аның өстеннән куе зәңгәр йон кофта.* Д.Каюмова

**ЯКАЛЫК** *и.* **1.** Якага җитәрлек, якага ярарлык, яка өчен билгеләнгән материал, мех һ.б.ш. *Синең бу койрыгыңнан хатыныма бер дигән якалык чыгачак, я бүрек.* А.Хәсәнов. *Әйдә, кибеттән якалыклар алабыз да дөньяда юк фасонлы бүрек тектерәбез.* М.Маликова

**2.** *с. мәгъ.* 1) Яка тегү өчен билгеләнгән, яка тегәргә яраклы; якага җитәрлек. *Һәртөрле әгълә мехлар, камчат, камалар, якалык һәм бүреклек каракүлләр...* Г.Әпсәләмов

2) Яка тегәр өчен мех, материал сатып алырлык. *Якалык акча*

**ЯКА́ ЧЫЛБЫРЫ** *и. этн.* Хатынкызларның муенына тагу өчен, ике-өч рәт чылбырга көмеш тәңкәләр тезеп ясалган бизәнү әйбере. *Чынаякны алганда, аның алдына таба зур, озын яка чылбырлары, берсенә берсе бәреләбәрелә, алга таба бөгеләләр.* Г.Исхакый. *Сөем тутайга яка чылбыры, алтын-көмеш тәңкәләр, затлы күлмәкләр, кәшимир яулыклар, Сөен оланга сөяк саплы пәкеләр, булат хәнҗәрләр – тагы әллә ниләр бүләк ителде аларга ул көнне.* Р.Батулла

**Я́КИ** *терк. фар.* 1) *к.* **яисә**. *Әлбәттә, кешенең «мин бәхетле» яки «мин бәхетсез» дип әйтергә хакы бар.* Л.Шагыйрьҗан. *Кышларын исә кыенрак: салкын мунчада яки сәндерәдә күпме генә киенеп-төренеп утырсаң да, бермәлне салкыннан тешләр тешкә бәрелә башлый.* А.Әхмәтгалиева

2) Һәр тиңдәш кисәк алдында кабатланып килеп, шулар белдергән нәрсәнең, эш-хәлнең берсе генә һичшиксез реальләшүгә басым ясый. *Өченче күрешүдә инде гашыйклар яки кавышалар, яки мәңгелеккә аерылалар.* Г.Рәхим

**ЯКЛАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **яклау**. *Күптән түгел аның гыйльми җитәкчелегендә мәктәп укытучысы Нурулла Гарифның татар телендә «Казан ханлыгында Чаллы олысы» дигән темага диссертация яклаганын гәзиттән укып белгәч, галим белән кызыксынуым тагы да арткан иде.* А.Тимергалин. *Шуннан соң Рафисның зары кимеде, диссертациясе дә, төгәлләнеп, бик тиз якланды.* Н.Гыйматдинова

2) *сөйл.* Кылану, кылтаю. *Чәчләрен маңгайга өеп, Борыннарын күккә чөеп, Йөриләр бит якланып.* Т.Миңнуллин

**Яклана башлау** Якланырга тотыну. *Ел саен фольклористика шифры буенча күпсанлы диссертацияләр яклана башлый.* Фәнни Татарстан

**Якланып бетү** Тулысынча яклану; барысы да яклану. *Чөнки нәкъ менә бүген балалар безнең җәмгыятьтә хокукый яктан да, социаль яктан да якланып бетмәгән катлам санала.* Кәеф ничек?

**Якланып китү** Билгеле моменттан алып яки кинәттән яклану. *Бу чаклысын белмиләр һәм, моны белмичә торып, артык якланып китәргә уңайсызланалар иде.* Ф.Хөсни

**Якланып тору** Даими яклану; хәзер, әле яклану; күпмедер вакыт дәвамында, озак вакыт яклану. *Шуңа күрә диссертацияләр дә якланып тора, конференцияләр дә гөрләп үтә.* Д.Булатова

**Якланып утыру** *сөйл. к.* **якланып тору.** *Якланып утырма монда! Бианаңа хәл белергә кермәгәнсең бит!* Р.Гаязетдин

**Якланып яту** *сөйл. к.* **якланып тору.** – *Урыс кешесе эшкә чыкмыйча эчеп ятса да сүз әйтмиләр – аларның өе, хуҗалыгы, тирән тамырлы туган-тумачасы, хөкүмәте-дәүләте бар, шуларга якланып ята, – дип өстәде Сеитислам.* А.Хәлим

**ЯКЛАНУЧЫ** *и.* Хөкем органында, мәхкәмәдә яклаучы тарафыннан яклана торган кеше. *Бу сорауларга җавап тапмыйча торып, минем якланучымны гаепләү бернинди дәлилләр белән дә расланмаган килеш кала бирә.* Ә.Сафиуллин. – *Алай да минем якланучы җавап алырга хокуклы, – дип сүз кыстырды адвокат.* М.Әмирханов

**ЯКЛА́У** *ф.* 1) Кемне дә булса рәнҗетергә, кимсетергә бирмәү, канат астына алу. – *Сез барыгыз да бер, барыгыз да ирләрне яклыйсыз! – дип әрләште.* Г.Ибраһимов. *Шул хәлдән соң Ага-Базар сәүдәгәрләре аны һәрчак якладылар, кирәк чакта акчасын да бирделәр, «юмарт хан» дип, исемен дә дөньяга тараттылар.* М.Хәбибуллин

2) Кемгә дә булса теләктәшлек итеп, аның карашларын, мәнфәгатьләрен хуплау; көрәштә, бәхәстә бер якта булу, шул як өчен көрәшү. *Хәмдүнә, бөтен акылын, бөтен сабырлыгын җыеп, үз халкын яклады.* Д.Каюмова. *Ә абый аларны яклады, акчага ялган шаһитлар сатып алды.* З.Мәхмүди

3) Кемне яки нәрсәне дә булса өстен күрү, хуплау, яхшы дип табу. *Югарыдан килгән карарны якларга кушасың!* М.Вәлиев. *Кайбер әти-әниләр дистанцион укуны яклады.* Кызыл таң

4) Диплом, проект, диссертация һ.б.ш. фәнни яки иҗади хезмәт махсус советта яки утырышта тикшерүгә куеп бәяләүгә ирешү һәм тиешле квалификация алу. *Әле күптән түгел генә Р. Ганиеваның бер шәкерте «Тукай иҗатында Коръән мотивлары» дигән темага кызыклы диссертация яклады.* Н.Хисамов. *Ничек кирәк алай бу чорны үткәрделәр, Лениза да ире әзерләп биргән дипломны яклады – ул чәйнәп биргәннәрне комиссия каршында шартлатып сөйләде.* М.Маликова

5) *махс.* Суд эшендә гаепләнүченең адвокаты булу; гаепленең мәнфәгатьләре сагында тору. *Син инде, Иван Васильевич, башка гаепләнүчеләрне дә якларга тырыш.* Һ.Такташ

6) Кеше хокукларын бозарга, аларны кыерсытырга юл куймау; кемнең дә булса мәнфәгатьләре өчен, гаделлек өчен көрәшү. *Район түрәләре белән сугыша торган, үз хокукларын якларга теләгән кешеләр табыла, аларның сезнең кебек ялгыз пикетларга чыгасы килсә, нинди киңәш бирер идең?* Р.Бикмөхәммәтова. *Халык үз хокукларын үзе якларга тиеш.* Н.Алан

7) Яхшы яктан таныту, яхшы яктан күрсәтү, күтәрү (дан тур.) *Шуны әйтергә кирәк: комсомолдан чыккан шушы егетләр белән без Азнакай районының данын якладык.* Ә.Исхаков

**Яклап бетерү** Җитәрлек яклау; бик күп яклау. *Башка халыкларда булса, әлбәттә инде, андый галимнең бөтен хезмәтләрен туплап том-том итеп чыгарырлар, аның эшчәнлеге турында әллә ниткән диссертацияләр язып-яклап бетерерләр иде.* М.Мәһдиев

**Яклап йөрү** Озак вакыт дәвамында яклау. *Еллар үтеп, көнчыгыш тарафында көн күргән кардәшләрен яклап йөргән арада, туган якларында калган колак тешләшкән насыйбы киявгә дә чыгып өлгергән икән шул.* М.Хәбибуллин. *Син, кыр үрдәкләре, пошиларны яклап йөри торгач, иң мөһим мәсьәләләрне читтә калдырдың.* Р.Батулла

**Яклап калу** Якларга өлгерү; форсаттан файдаланып яклау. *Яклап кала алмадым мин сине, өлгермәдем.* В.Имамов. *Ул вакытта чынлап та зур бәладән коткарып, яклап калды аны Булат.* Г.Гыйльманов

**Яклап кую** Тиз арада яки алдан ук яклау. *Зәйнәп Вахитовнадан соң сүзне Роберт алды. Ул иң әүвәл кафедра мөдиренең фикерен яклап куйды.* Ә.Сәйфетдинов

**Яклап тору** Һәрвакыт, даими яклау; сөйләү моментында яклау. *Хәзерге яшьләрне, билгеле, аңламассың, әнә бит Әлфия дә шуны яклап тора.* Н.Акмал. *Менә анда инде редактор Ларисаның андый гамәлләрен ачыктан-ачык яклап торды.* З.Мифтахов

**Яклый башлау** Якларга керешү. *Дәррәү кубып Сәетне яклый башладылар.* М.Хәсәнов. *Шулчак ярлы агай, боларның арасына кереп, берсен яклый башлаячак, ә икенчесе, моңа үпкәләп, кунакны өйдән куып чыгарачак.* Р.Вәлиев

**Яклый тору** Нәрсәдер башланганчы, ниндидер вакыт җиткәнче яклау. *Әлегә үз мәнфәгатьләребезне үзебезгә яклый торырга кирәк.* Безнең гәҗит

**ЯКЛАУЧЫ** *и.* 1) Кемне дә булса төрле кагу-сугулардан, рәнҗетүләрдән яки һөҗүмнән саклаучы. *Дус кирәк миңа, киңәшче, юаныч, яклаучы, таянычкирәк.* А.Гыйләҗев. *Ләкин шунысы бар: котыртуын яклаучылары булган малайлар котыртса да, кыены безгә – ятим малайларга эләгә!* В.Нуруллин

2) Кемнең дә булса карашын, сүзен, фикерен хуплап, аның ягында булган кеше, тарафдар. *Депутат дәрәҗәсен йөрткән кеше, минемчә, ул халык яклаучысы булырга тиеш.* В.Имамов

3) *махс.* Судта гаепләнүчене яклаучы юрист, адвокат; аклау өчен көрәшүче. *Хөкемнең рәисе, әгъзалары, прокурор, яклаучылар, гаепләнүчеләр, бер-бер артлы яудырган сораулары белән өзгәли торгач, Садыйкны менә шул зур чуалчык күренешне бүлгәли-бүлгәли сөйләп чыгарга мәҗбүр кылдылар.* Г.Ибраһимов. *Яклаучы, сез чыгыш ясарга әзерме, рәхим итегез.* З.Мурсиев

4) *сөйл.* Башка берәү өчен киңәшче, ярдәмче, терәк булырлык, аңларлык, ярдәм кулы сузарлык кеше. *Күңел кояшым, өмет йолдызым, таянычым, яклаучым бул!* Р.Габделхакова. *Адәм баласы фикердәшкә дә, терәк-таянычка да, яклаучыга да мохтаҗ.* М.Кәбиров

**ЯКЛАШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **яклау**. *Без бөтен нәрсәдән куркабыз: кызларны яклашсак – каян килгән Урта гасыр рыцаре, дип үртәүләреннән.* Ф.Яруллин. – *Бер-берсен яклашалар, алдашырга өйрәнәләр... – дип, җилкенеп, тышка чыгып китте.* С.Поварисов

2) *диал. к.* **яклау** (*1 мәгъ.*). *Беренчесе – аның җанындай кадерле, сине гомер буе яклашкан дустыдай газиз, икенчесе яңа кием кебек ияләшелмәгән, күнегелмәгән иде.* Ф.Яруллин. *Картәнисенең аны түгел, киявен яклашуына отыры ачуланып, кыз, иреннәрен тешләп, ат*

*муенына ябышкан канга туймас бөҗәкләрне «чаба».* Д.Булатова

**Яклаша башлау** Яклашырга керешү. – *Ул шәһәрдә яши ич! Анда бөтенесе русча гына сөйләшә, татар теле аңарга кирәк түгел, – дип яклаша башласаң, үзебезгә дә шәп кенә эләгә.* Р.Мулланурова. *Шушы Саша Хәлимәгә игътибар итә һәм аны классташларыннан яклаша башлый.* Сөембикә

**Яклашып йөрү** Әле, хәзерге вакытта яклашу; озак вакыт дәвамында яклашу. *Бигрәк каты орынасың инде, Фәһимә, баланың күңеле болай да китек, дип, әни яклашып йөри тагын.* Л.Ихсанова

**Яклашып килү** Электән үк, һәрвакыт, эзлекле рәвештә яклашу. *Рузил үзе дә хатынына бер яман сүз дә әйттерми иде, аны гел яклашып килде.* Өмет

**Яклашып тору** Һәрдаим яклашу; сөйләү моментында яклашу. *Кара, кара, Галиенә тиклем яклашып тора.* Г.Госман. *Ә сез яклашып тормагыз, бериш булып...* Н.Хәсәнов

**ЯКЛЫ** I *с.* **1.** Ягы яки яклары билгеле санга, билгеле сыйфатка ия булган. *Берничә яклы өй*

**2.** *хәб. функ.* Кемнең яки нәрсәнең дә булса тарафдары булу, шуны яклау. *Юк, япон балалары да сугыш теләми, алар да тынычлык яклы.* Р.Миңнуллин. *Математик Хәбирә – хәйләкәр, директор яклы!* Р.Камал

**ЯКЛЫ** II *бәйл.* Алда аталган кем яки нәрсә ягында булган, шуңа теләктәшлек иткән, кемне яки нәрсәне яклаган. *Әгәр ул мине гаепсез дип уйлаган булса, минем яклы кешеләрнең башын чаптырмаган булыр иде!* Н.Фәттах. *Дөреслек яклы кешеләре дә табыла шул ук трамвайда.* Т.Галиуллин

**Я́КОРЬ** *и. гр.* Үзенең ыргаклары белән җиргә эләгеп, судноларны һ.б. йөзмә объектларны бер урында тота торган махсус авыр тимер җайланма; ләңгәр. *Гади генә һәйкәл иде бу: биек нигез өстенә якорь куелган, аңа, тынлыкны һәм тынычлыкны сакларга теләгәндәй, калын кар мендәре яткан.* М.Маликова. *Елга уртасында гына су төбенә якорь ташлап, кәрван үзе җиде-сигез дилбегә арасы читтә торып калды.* В.Имамов

**ЯКТАШ** *и.* **1.** Кем белән дә булса бер якта (авылда, районда һ.б.ш.) туып үскән яки яшәгән кеше. – *Солтан, синең якташ килгән, тор! – дияргә өлгерә алмадылар, мин, атылып барып, дустым Шаһбазны кочакладым.* Г.Ибраһимов. *Якташ, дигән булды, ярар бер юлга, диде, бер тотылгач, акылга утырмасмы, диде.* Г.Гыйльманов

**2.** *с. мәгъ.* Бер яктан булган; туып үскән яки яшәгән җирләре уртак булган. *Рәхәтләнеп ял иттек якташ егетләр белән.* Т.Миңнуллин. *Соңыннан якташ хатын-кызлар, яныма килеп, миңа шушы җырым өчен рәхмәтләр әйтә башлагач, Хәйдәрне дә чакырып алдым.* Р.Миңнуллин

**ЯКТАШЛЫК** *и.* 1) Якташ булу. *Якташлык шикелле, яшьтәшлек тә кешеләрне якынайта.* Ш.Галиев

2) Үзара ярдәмләшү, элемтәдә тору һ.б. максатыннан, бер районда, илдә туып үсеп, башка җирдә яши торган кешеләр тупланган берләшмә; якташларны берләштергән оешма. *Киевтагы мөселман студентлары «Якташлык җәмгыяте» төзегән.* С.Поварисов. *Вахит Имамовны Чаллыда яшәүче Актаныш кешеләренең якташлык җәмгыяте президенты итеп сайлаганнар.* Р.Миңнуллин

**ЯКТЫ** *и.* **1.** 1) Кояш нурлары тәэсирендә барлыкка килгән яктылык. *Бердәнбер форточкадан төшкән көн яктысы бу зур бүлмә өчен һич тә җитәрлек түгел иде.* Г.Әпсәләмов. *Гөлтуташ кабат әйләнеп кайтып кергән чакта, таң яктысы беленеп килә иде.* В.Имамов

2) Гомумән нинди дә булса утлы, кызган җисемнән нурланып тарала һәм тирә-якны яктырта торган энергия. *Иксез-чиксез төн караңгысында учак яктысы үзенә күрә бер кызгылт утрау булып, әкиятләрдәге төсле серле булып күренә.* Г.Бәширов // Нинди дә булса чыганактан тарала торган яктылык. *Бу урманның эчендә кич белән бик ерактан бер якты күренә.* Фән һәм тел. *Тәрәзәләр тышкы яктан якты күренмәслек итеп капланган, чөнки авыл өстеннән очкыч эскадрильялары туктаусыз очалар.* Ватаным Татарстан

3) Яктылык килә, төшә торган урын; нәрсә белән дә булса яктыртылган урын. *Аулаккарак китик, алайса монда яктыга озынборын, черкиләр дә күп җыелган.* Т.Әйди

4) *күч.* Шатлыклы хисләрнең күзләрдә, йөздә чагылышы. *Йөзләрдә әле шатлык яктысы, әле сагыш күләгәсе чагылып китә.* Ф.Яруллин. *Зәринәнең күз алдыннан Рәхиләнең баласына төбәлгәндә бәхет яктысы кабынган күзләре китмәде.* Сөембикә

5) *күч.* Аң-белем, мәгърифәт, культура, гыйрфан. *Китап – безнең турылыклы дустыбыз – һәрчак яктыга илтер, тормышыбызны ямьлерәк, мәгънәлерәк итәр.* Р.Фәйзуллин // Яхшылык. *Гел яктыга, киләчәккә таба карыйк.* А.Нәҗми

**2.** *с. мәгъ.* 1) Көчле яктырта торган; яктылыгы көчле булган. *Чөнки аның үз тәрәзәләрендә дә якты ут балкый, аның үз өендә дә күңелле мәҗлес.* Г.Әпсәләмов. *Көнозын кояш җир йөзен үзенең якты нурлары белән иркәли, яңа тормыш, яңа сулыш, яктылык һәм җылы бирә.* А.Нәҗми

2) Яхшы яктыртылган; яктылык күп төшә торган. *Буяу исе аңкып торган ике бүлмәле өр-яңа якты фатир иде бу.* Ә.Салах. *Оҗмахтай җылы, якты бүлмә, дип уйлады ул, тәрәзә пәрдәләре, өстәл, карават җәймәләре, вазадагы чәчәкләрне күздән кичергәч.* Д.Каюмова

3) Караңгыда бик ачык күренә торган; нурлы; нур тарата торган (төнге күк җисемнәре тур.). *Әнә, баш өстендә диярлек, якты йолдыз.* А.Тимергалин. *Кичләрен көзге күкне санап, карап бетермәслек якты йолдызлар каплап алалар.* А.Нәҗми

4) Кояшлы, аяз; яктылыгы күп булган. *Бераздан күзне ачсам, якты көн кара күзлек аша карагандай сүрәнләнеп, тонykланып калган.* Ш.Галиев // Караңгы төшеп өлгермәгән; кояш баемаган. *Һәркем, якты чакта тизрәк өенә кайтып җитәргә дип, дүрт күз белән теге яктан паром чыкканны көтә.* А.Хәсәнов

5) *сөйл.* Ачык; караңгы, кара төскә тартым булмаган (төс тур.). *Дөрес, безгә якты, алтынсу төсләргә ялтыравыклы обой әлакте – очсыз булса да, хәтәр матур күренә.* А.Әхмәтгалиева. *«Авыр», калын, караңгы төсләрдәге тәрәзә пәрдәләре урынына, киресенчә, юка, яктыларын алыгыз.* Кызыл таң

6) Чиста; болганмаган; үтәкүренмәле (сыеклык, сулык тур.). *Суы үтә күренгән якты диңгезгә карыйм да авылымдагы Дымбылат кизләве искә төшә.* Ш.Галиев. *Ә бит йөрәк талпынган иде, күңел якты елга өстендә салмак кына чайкалып торган ак пароходка таба очынган иде.* М.Маликова

7) *күч.* Ачык, көләч. *Күптәннән якты чырай күргәнебез һәм күрсәткәнебез юк.* А.Гыйләҗев. *Әнисенең болай да якты йөзе тагын да илһамланып яктырды.* А.Хәлим // Мөлаем, нурлы, үзенә тартып тора торган. *Аның йөзе якты, йөзе яктының күңеле дә якты була.* Т.Миңнуллин

8) *күч.* Бернинди күңелсезлек белән дә бозылмаган; бәхетле, ямьле, шатлыклы, рәхәт, тыныч (тормыш тур.). *Якты, шатлыклы, өмет уята торган көннәребез дә хәтердә.* А.Тимергалин. *Ләкин ул кеше Чүкәйгә килеп эшли башлаган сәгатьтән алып, Равилнең бәхетле, якты көннәрен кара болыт баскан иде инде.* В.Нуруллин // Күтәренке күңелле, оптимистик; рухны күтәрә торган, позитив. *Якты уйлардан канатланып киткән Валя, үзе дә сизмәстән, Ерганак урамына йөгерде.* З.Мәхмүди. *Әлегә кадәр аның әтиемне һаман яратуын белү миңа яшерен өмет, килер көнгә ышаныч, якты хыял бирә иде.* А.Әхмәтгалиева

9) *күч.* Аң-белемгә, мәгърифәткә илтә торган; әхлакый, эстетик тәрбия бирә торган; яхшылыкка өйрәтә, өнди торган (иҗат тур.). *Тулаем алганда, оптимистик рухлы әсәр туган, киләчәк буынга карата хәерхаһлык белән сугарылган, бүгенге авырлыклар алдында рухи сынау үтә торган яшьләрне белеп тасвирлаган якты пьеса барлыкка килгән.* А.Әхмәдуллин. *«Әлдермештән Әлмәндәр» пьесасы да үзенең ачык һәм якты, оптимистик фикерле булуы белән характерлана.* Казан утлары

10) *күч.* Саф күңелле; башкаларга яхшы мөнәсәбәттә булган; сокланырлык, үрнәк алырлык. *Остазсыз ярамый, өйрәтүчесез булмый, тереме ул, үлеме, сәнгатьтә син олылаган, син табынган, юлыңның дөреслеген алар иҗаты белән дөресли торган якты шәхесләр булырга тиеш.* А.Гыйләҗев

11) *күч.* Күңелгә җылылык бирә торган; уйлаву, искә төшерүе рәхәт булган; бары тик яхшылыктан гына торган. *Үземнән соң якты рух калдырмый, Җир йөзендә тик мал калдырсам...* И.Юзеев. *Гел-гел үткәннәр белән яшәп булмый, Җиһанша абзасының якты рухы тәэсир иттеме, Аксу авылына күчеп килгәннән бирле, авыр хатирәләр читкәрәк киткәндәй булдылар.* А.Гыйләҗев

12) *күч.* Ачык, аңлаешлы, аник (уй, фикер тур.). *Кинәт, гөлт итеп, Әхияр картның зиһенендә бер якты уй кабынып китте.* Г.Гыйльманов

◊ **Якты дөнья** Фани дөнья; тормыш. *Вакыт-вакыт үзен бу якты дөнья өчен чит итеп тә тойды.* Р.Сибат. *Бу якты дөньяда караңгыга да урын җитәрлек.* А.Тимергалин. **Якты дөнья белән бәхилләшү** *к.* **якты дөнья белән хушлашу** *Әгәр кайчан да булса мине алдарга җөрьәт итсәң, сиңа якты дөнья белән бәхилләшергә туры килер.* Р.Вәлиев. *Миңа теге тол әби дә картаеп, якты дөнья белән бәхилләшә.* Т.Нәҗмиев. **Якты дөнья белән саубуллашу** *к.* **якты дөнья белән хушлашу**. *Ярый әле, сихерле балдагы миндә калды, якты дөнья белән саубуллашкан булыр идем.* А.Гадел. **Якты дөнья белән хушлашу** Үлү; бакыйлыкка күчү. *Усалбай хәзер үзе дә картайды, тиздән аңа якты дөнья белән хушлашырга туры килер, ә аманәте үтәлмәде.* З.Мурсиев. *Ул якты дөнья белән хушлашты: мине, ялгызымны калдырып, мәңгелеккә ташлап китте.* А.Мансуров. **Якты дөньяга аваз салу** *к.* **якты дөньяга килү**. *Менә-менә якты дөньяга аваз салам дип торган баласы ничек түзгәндер бу изалануларга – Ходай гына белсен!* Г.Гыйльманов. **Якты дөньяга килү** Туу. *Вакыты җитеп, якты дөньяга килгәч, мин синең җылыңны, назыңны ныграк тоя башладым.* Ф.Тарханова. *Менә ул якты дөньяга килә, беренче мәртәбә көн яктысы, кояш нурлары белән очраша.* Г.Гыйльманов. **Якты исем** Хөрмәт белән искә алына торган кеше; кешенең даны. *Үзгәртеп кору чоры башлангач, Исхакыйның якты исеме һәм әсәрләре яңадан татар халкына кайта, инде мәңге китмәскә дип кайта.* Ф.Бәйрәмова. *Татар халкы тарихы азатлык, бәхет өчен һәм илнең чәчәк атуы өчен аяусыз көрәшкән, якты исем калдырган батыр шәхесләргә бай.* Р.Фәхретдинов. **Якты йөз белән** 1) Ягымлы итеп, матур итеп; шатланып, елмаеп, ачык чырай, яхшы кәеф белән. *Чаршау эченә кергәч, озынчарак буйлы, аксыл чырайлы бер хатын якты йөз белән Гөлбануга: – Менә, сеңлем, шушында утыр, – дип, ларга охшатып ясалган бер кечкенә әрҗә өстендә урын күрсәтте.* М.Хәсәнов. *– Әгәр инде безне, чакырылмаган кунакларны, ипи-тоз, якты чырай, якты йөз белән каршы алырга теләсәгез, үзегез монда чыгыгыз, – диде калын тавышлысы.* А.Хәсәнов; 2) Тыныч намус белән, бернәрсә өчен дә оялмыйча; хаклы рәвештә горурланып. *Без быелгы сабантуйга якты йөз белән киләбез.* А.Хәлим. *Район җитәкчеләре Казанга пленумга, сессиягә, киңәшмәгә чакырылса, алар якты йөз белән барырга тиеш, дип кысалар: күбрәк чәчелсен, күбрәк урылсын, күбрәк тапшырылсын, сөтне әйтеп тә торасы юк.* Ф.Садриев. **Якты йөз күрсәтү** Ачык булу, яхшы мөнәсәбәттә булу, кунакчыллык күрсәтү. *Ярый ла, якты йөз күрсәткәч, синең ямаулык сорый торган гадәтең бар икән әле, дип төрттереп куймаса.* М.Хәсәнов. *Хуҗалар якты йөз күрсәттеләр.* Н.Фәттах. **Якты йөз, тәмле сүз** Ачык йөз, якты чырай *к.* **якты йөз белән**. *Бусагадан атлап кергән һәр кешегә якты йөз, тәмле сүз булды.* Р.Габделхакова. *Борынгыларча әйтсәк, якты йөз, тәмле сүз – максатларга ирешү ачкычы.* Э.Халидов. **Якты көн** Тынычлык; рәхәт тормыш; тыныч, матур тормыш. *Шулай итеп, бу йортта Заһидәнең үзенә дә, кызы Габидә белән угылы Җиһанга да һичбер якты көн калмый, аларга сан бетә, кадер бетә...* Г.Ибраһимов. *Без – изелгән мөселман хатыннары – гомер буе ирләргә кол булып яшәдек, якты көн күрмәдек!..* А.Гыйләҗев. **Якты көн бирмәү** Кемне дә булса кимсетү, рәнҗетү, тынычлыкта яшәтмәү, кайгы эчендә тоту. *Егетен дә бик мактап бетермиләр, кайнана – бик эт нәрсә, ди, Гөлбануга бер дә якты көн бирмәс, диләр.* Г.Ибраһимов. **Якты көн күрсәтмәү** *к.* **якты көн бирмәү**. *Синең ишеләргә хәзер барыбер якты көн күрсәтмиләр бу вафасыз дөньяда.* З.Мәхмүди. *Аңа якты көн күрсәтмәгәннәр, колхозларында эш тә табылмаган!* Ф.Яхин. **Якты күздә** Караңгы төшкәнче, көндез; якты вакытта. *Якты күздә дип, көянтә-чиләген алып, җәһәт кенә су алып кайтты.* М.Хәсәнов. *Юлы озын – акрын атласа, барасы җиренә якты күздә барып өлгермәячәк.* Н.Әхмәдиев. **Якты таң** Авыр, дәһшәтле, кайгылы көннәрдән соң килгән тыныч, бәхетле, ямьле тормыш турында. *Алга атла, алга, егет, алда – якты таң, Мәңге онытылмас ирек өчен безнең түккән кан.* М.Җәлил. *Татар йорты биргән сиңа якты таң.* Ә.Гадел. **Якты чырай белән** *к.* **якты йөз белән** (*1 мәгъ.*). *Кардәшләре аны кочак җәеп, якты чырай белән каршы алдылар, әмма ул көткән җылылык, якынлык сизелмәде.* М.Маликова. *Бабасы Хәниф тә, әбисе Тәзкирә дә кияүләрен якты чырай белән каршы алды.* Н.Әхмәдиев. **Якты чырай күрсәтү** *к.* **якты йөз күрсәтү**. *Хәерчегә якты чырай күрсәтсәң, ул ямаулык сорар, дигән атайбабай.* В.Имамов. *Язиләнең үпкәләве әйбәт анысы, якты чырай күрсәтсә, муенына асылынып елый башласа, ялынып ялварса, кызганып, шушында яшәп калуың бар бит.* К.Кәримов

**ЯКТЫЛЫК** *и.* 1) Нинди дә булса чыганактан килгән якты (*1–2 мәгъ.*). *Өске яктан нурлы яктылык сирпелә, шуңа күрә һәр таш кисәге, һәр тузан бөртеге аермачык булып күренеп тора.* Г.Гыйльманов. *Ишектән кергән кечке яктылык тонык кына булып амбар эченә таралды.* С.Зыялы

2) Күк җисеменнән, уттан һ.б.ш. чыккан якты нурлар. *Галәмдәге йолдыз яктылыгы, әкренләп, безнекеләрнең дә күңеленә төшәр әле!* Р.Фәйзуллин. *Багана башындагы утның яктылыгы йөзләренә төшә.* Т.Галиуллин

3) Якты, ачык төсле булу; шуннан барлыкка килгән матурлык тәэсире. *Ачык төсле җылы буяулар бу максатка ирешүдә аңа ярдәм итәләр, картинага бәйрәм рухы һәм яктылык өстиләр.* Р.Вәлиев. *Каеннарның ап-ак кәүсәләреннән илаһи бер яктылык бөркелә, бу яктылык үзеннән-үзе күңелгә күчә, җанны тынычландыра.* Д.Йосыпова

4) *күч.* Шатлык, канәгатьлек хисләренең чагылышы; нурлы йөз; елмаю. *Мостафа белән Шәрифнең дә йөзенә яктылык кунды.* А.Әхмәтгалиева. *Кулга-кул тотынышкан ике йолдыз, йөзләрендәге бәхет яктылыгы белән, өч тапкыр, шәфәкъ-тай янган учак тирәли әйләнделәр.* А.Нәҗми

5) *күч.* Күңелне, рухны күтәрә торган хис-кичерешләр, күңелгә рәхәтлек бирә торган тәэсирләр. *Кешегә көн саен нииндидер яктылык, матурлык кирәк, шул чагында ул бауга тотынмас.* З.Хәким. *Ә бит һәр очрашу, һәр аралашу күңелдә нииндидер җылылык, яктылык калдыра, аны баета, хәтта сафландыра, изгелеккә якынайта...* Г.Гыйльманов // Уңай, позитив энергия; җылылык. *Бирәү үзеңә, кешеләргә яктылык сирпеп, яхшылык бөркеп, кәефеңне күтәреп китә.* Г.Хөсәенов. *Ул агайдан да нииндидер җылылык, яктылык сирпелә сыман.* З.Мурсиев

6) *күч.* Матур, бәхетле тормыш, якты киләчәк. *Һәр туган көннең иртәсе аңа яктылык, шатлык-куаныч, күңел көрлеге алып килә торган иде.* М.Хәсәнов. *Караболак, туган авыл, туган нигез, нәсел-ыру алар өчен әнә шундый яктылык, шатлык чыганагы иде.* Ф.Бәйрәмова

**ЯКТЫЛЫ́-КАРАҢГЫЛЫ** *с.* 1) Бик якты да һәм бик караңгы да булмаган; эңгер-меңгер. *Кинодан чыкканда шәһәр өстенә эңгер иңеп, бар дөнья аның кәефе сыман яктылы-караңгылы иде инде.* Р.Вәлиев. *Бирдә яктылы-караңгылы иде.* Безнең гәҗит

2) *күч.* Бәхетле-бәхетсез, яхшылы-начарлы, уңышлы-уңышсыз. *Бу вакытта Гайниҗамалның күңеле еракларга – үзенең башыннан үткән, күптәнге яктылы-караңгылы, шатлыклы-кайгылы хәлләргә карап очадыр иде.* Ш.Камал

**ЯКТЫРТКЫЧ** *и.* **1.** 1) Люстра, лампа кебек, торакны яки урамны яктырту өчен кулланыла торган прибор. *Хуҗалык мөдире өстәл, урындык, яктырткыч, шкаф, жардиньеркаларны, тәрәзә пәрдәләрен санады.* Н.Көбәш. *Стеналардагы тонык яктырткычлардан шомлы күләгәләр сузылып киткән.* Л.Гыймадиева

2) Яктылык чәчә торган яки якты булып күренә торган күк җисеме. *Гомумән, Кояшка, Айга һәм башка күк яктырткычларына игътибарлы күз белән карау мөселманның канында бар.* А.Тимергалин. *Галәм яктырткычларын үзгәртеп булмаган кебек, вакытны да туктатып булмый.* А.Нәҗми

3) Төрле махсус максатларда кулланыла торган яктырту приборы. *Күн пинжәк кигән ике ир, өстәлнең як-ягына утырып, сүзсез генә сумкаларын ачтылар, аппаратларын көйли, яктырткычларын куя башладылар.* Р.Вәлиев

4) Транспортның алгы өлешенә урнаштырылган, кайтаргыч яктылык бирә торган батынкы көзгеле фонарь; фар. *Аның каравы бәхәс шарты буенча, өр-яңа сәпит яктырткычы Җәмилнеке булды.* А.Гыймадиев. *Ә каршыга килүче машинаның яктырткычы сине йокыдан айнытa.* Безнең гәҗит

5) Караңгы урыннарда вакытлыча яктыртып алу өчен, көнкүрештә кулланыла торган зур булмаган кул приборы; фонарь. *Заварзин янында басып торган Гыйният кул яктырткычының төймәсенә басты.* З.Зәйнуллин

6) *күч.* Борчуларны бетерә, караңгы уйлардан арындыра торган кеше турында. *Булмадың алтын ярым, салкын ярым син дә минем, Бер тәбәссем берләрдә тормыш юлым яктырткычы!* Г.Тукай

**2.** *с. мәгъ.* 1) Яктырта, яктылык бирә торган, яктылык чыгара торган. *Якты август төне безнең яклы: бүген яктырткыч ракеталар кирәк булмаячак.* А.Тимергалин. *Аннан ул өч-дүрт фотоаппарат алып чыкты. Миңа яктырткыч лампалар тоттырды.* М.Садыйков

2) Төнлә якты булып еРактан күренеп тора торган (бөҗәкләр тур.). *Яктырткыч бөҗәкләр җыйдык та чөйдек учлап төнге урманда!* Р.Фәйзуллин. *Ай нурына уралган беренче кичтәге тойгылары бөтенләй үк онытылмаган, карурмандагы яктырткыч кортларның ымсындыргыч яктысы рәвешендә генә булса да, вакыт-вакыт чагылып ала иде әле.* М.Маликова

**ЯКТЫРТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **яктыру**. *Бу карашы аның пөхтә итеп кырылган, нык ияклe кырыс йөзен яктыртып, аңа мөлаемлык өстәп тора иде.* М.Маликова. *Әти, әйләнә-әйләнә, күзгедән үзен күзәтә, канәгатьлек билгесе бөтен йөзен яктыртып, балкытып тора.* И.Нәбиуллина

2) Яктылык бирү, якты итү. *Кояшның бар дөньяны – тау итәкләрен, елгадагы агымсуны, урман-кыр, болыннарны яктыртып, көнчыгыштан көнбатышка таба китеп барган чагы.* А.Нәҗми

3) Караңгыда күренсен өчен, яктылыкны нәрсәгә дә булса юнәлтү. *Аңа бара торган аллея иң матур фонарьлар белән яктыртылган, зифа буйлы пальмалар, кипарислар сарайны чолгап, бизәп торалар.* А.Гадел. *Тар гына прожектор уты авансценаның уң як читенә, борынгы кәнәфидә утырган Рәсүлне яктырта.* Г.Каюмов

4) *күч.* Матур итү, якты (*11 мәгъ.*) итү, матур күренерлек итү; бәхетле итү. *Бер елмаю белән дөньяны яктырта беләләр иде шул!* М.Маликова. *Синең нурлы йөзең каршымда, Йолдыз кебек балкый, Тормышымны яктырта ---.* А.Җамал // Яхшырту. *Әй син, кеше, кылган эшләрең дөньяның кай җирен булса да яктырттымы?* Р.Низамиев

5) *күч.* Күңелен күрү, күңелен җылыту; шатландыру; куаныч бирү. *Андагы бер чәчәк кенә булса да, Синең күңел гамьнәреңә тәңгәл килеп, Синең җаныңны яктыртса, мин шат булырмын.* Г.Мөхәммәтшин. *– Имәндә икән чикләвек, – дип, кешеләр алдында елмаеп кына куйса да, Кадрияне әчтән икенче уй җылытып, яктыртып узды.* В.Имамов // Җанландыру, шатлык нурлары чыгару. *Кешеләргә йөз аклыгымны илт син, сөмсере коелганнарның да йөзләрен яктырт.* Л.Зөлкарнәй

6) *күч.* Җиңеләйтү; нинди дә булса ярдәм, җиңеллек бирү. *Шул язның бер көне, давыллы диңгездәге маяк шикелле, әле дә булса юлымны яктырта, иң авыр чакларда яшәү көче бирә.* М.Яһудин

7) *күч.* Аңлатып, төшендереп бирү; сөйләү, сөйләп бирү, тасвирлау. *XIX йөз*

*ахыры татар авылы тормышын М.Галәү кадәр масштаблы планда яктырта алган башка бер язучы да юк.* М.Мәһдиев

**Яктырта бару** Торган саен ныграк яктырту, эзлекле рәвештә яктырту. *Кояш күтәрелгәннән-күтәрелә барды, көнне җылыта, ныграк яктырта барды.* Н.Фәттах

**Яктырта башлау** Яктыртырга тотыну. *Әмма берсе дә күрмәде бугай, тагын бездән бөтенләй читкә яктырта башлады.* С.Сабиров. *Иң тәүдә район үзәген яктырта башларга кирәк тә инде.* З.Мурсиев

**Яктырта төшү** Бераз яктырту; ныграк яктырту. *– Минә Чернозубовның үзе утырткан ике түтәл бәрәңгесе, – диде Исхак, фонарь белән яктырта төшеп. – Мин, үз рөхсәте белән, көн саен бер төбен ашап торам.* Ә.Маликов

**Яктыртып алу** Аз гына, кыска вакыт яктырту; тиз генә яктырту. *Шул яктылык Мәрхәмбикәнең судан чыгып торган ап-ак йөзен яктыртып алды.* М.Хәсәнов. *Лифт эчендәге ут караңгы коридорны беразга гына яктыртып алса да, хатын аларның йөзләрен шәйләми калды, киемнәренә караганда, яшүсмерләр бугай!* З.Хөснияр

**Яктыртып бару** Даими, эзлекле рәвештә яктырту. *Кабатлап әйтәм: Нурия үзе, Америка турында язганда, уңай якны да, ошамаган якны да бертигез дәрәҗәдә яктыртып бара, күзе ни күрсә, йөрәге ни кушса – шуны яза.* М.Вәлиев

**Яктыртып бетерү** Тулысынча яктырту, бик нык яктырту. *Бер учак кына төнне яктыртып бетерә алмый.* Г.Гыйльманов

**Яктыртып җибәрү** Кинәт, көтмәгәндә яктырту; тагын да ныграк яктырту. *Алтын чәчле Пётр бөтен эчке дөньямны яктыртып җибәрде бугай...* К.Кәримов. *Хәтер метафорасы безне тормышның нинди катламнарына алып керә, кеше күңеленең кайсы караңгы почмакларын яктыртып җибәрә соң?* М.Вәлиев

**Яктыртып кую** Алдан ук яктырту; яктыртылган хәлгә китерү. *Интегеп, рәт араларында эзләп йөрисең дә булмый, сез кергәнче үк урыннарыгызны прожектор белән яктыртып куярмын, диде.* Аманулла. *Яктыртып куелган реклама тактасындагы «Ялта – дөнья курортларының энҗесе» дигән язу мәсхәрәләп көлү кебек тоела иде.* Р.Мирхәйдәров

**Яктыртып тору** Яктыртылган хәлдә тоту, даими рәвештә яктырту. *Әле генә төн караңгылыгын тишеп, су өстен яктыртып торган яшел һәм кызыл утлы маяклар көчсезләнеп калдылар.* Г.Гобәй. *Әдилә минем йон аякчуларымны, чабатаны мичнең буш калган урынына җайлап урнаштырды, мин, лампаны күтәреп, аңа яктыртып тордым.* А.Гыйләҗев

**Яктыртып узу** Берәр эш-хәл, сүз барышы уңаеннан яктырту. *Бу проблеманың асылын тәфсилләп тормастан, безнең бүген Русиядә туган телләр язмышына кагылышлы кайбер фикерләребезне тезислап булса да яктыртып узасыбыз килә.* Кызыл таң

**ЯКТЫРТУЧАН** *с.* Яктырту үзлеге булган, яктыртып тора торган. *Тигез яктыртучан прибор*

**ЯКТЫРТУЧАНЛЫК** *и. махс.* Йолдыз чыгарган яктылык егәрлегенең кояш чыгарган яктылык егәрлеге белән чагыштырмасы, нисбәте. *Ул – аксыл күк төстәге супергигант, аның чын яктыртучанлыгы Кояшныкыннан 67 мең тапкыр зур.* Фән һәм тел // Яктырту егәрлеге, яктырта алу дәрәҗәсе. *Йолдызларның яктыртучанлыклары төрле-төрле була.* Астрономия

**ЯКТЫРУ** I *ф. йөкл. юн. к.* **ягу** I (*1–4 мәгъ.*). *Бераз тынычлана төшкәч, Сирай бабай бәйрәмнәрдә генә кия торган ак күлмәген киеп алды, күрше Гатифәне чакыртып, коймак пешерттe, мунча яктырды.* Г.Сабитов. *Бәк түгәрәк аланны тутыртып учак яктырган икән, җылысы ике-өч йөз адымнан биткә бәрә.* М.Әмирханов

**Яктырып кую** Алдан ук яктыру. *Шулай да, булдыклы егетләребез гомуми мунчаны Илһам абый хөрмәтенә яктырып куйган иде.* Безнең гәҗит

**ЯКТЫРУ** II *ф.* 1) *з.-сыз* Таң ату, көн туу. *Таң да ата инде, яктыра.* И.Юзеев. *Яктырды, кояш та чыкты, ә мин, йоклый алмыйча, урын өстендә аунап ятам.* А.Шамов

2) Якты булып китү; караңгылык китеп, яктылык килү; яктыга әйләнү. *Чынлап та, Фәнис күптән чамалап килә инде: төнгә каршы табигать кискен үзгәрә икән – кар карая, ә төн агара, яктыра...* Г.Гыйльманов // Кисәк бик якты нурга, яктылыкка күмелү. *Бер мизгелгә фатир яктыра һәм кабат гөлтләп сүнә.* М.Кәбиров

3) Башка нәрсәдән аерылып, ачык, якты булып күренү, ялтырап күренү. *Стенада Хәмзиннең карикатурасы яктыра.* И.Юзеев. *Авансценаның икенче почмагы яктыра.* А.Гыйләҗев

4) *күч.* Наданлыктан, караңгылыктан арыну, агару, аң-белемгә ия булу; белем дәрәҗәсе арту. *Читтәге бик күп өяздә, күр, авыллар яктыра ---.* Г.Тукай

5) *күч.* Җанланып китү, шатлык билгеләре чагылу (йөз тур.). *Һәм яктыра йөзем: Һәрбер чыктан Халкым карый кебек елмаеп.* М.Шабаев. *Ут теле үрләгән саен, абыйның йөзе яктыра, елмаю булып иреннәренә, күзләренә елтыр балкыш куна.* Л.Зөлкарнәй

6) *күч.* Нурлану, очкынлану, шатлык нурлары күренү (күзләр тур.). *Гәүһәрнең нечкә иреннәрендә алсу нур уйнады, күзләре, яктырып, сөю ялкыны белән яна башлады.* Г.Ибраһимов

7) *күч.* Күңел ачылу, күңел күтәрелеп китү, яшәү дәрте арту. *Гаҗәеп аклыкка, гүзәл сафлыкка күңел үрләрем яктыра.* Н.Хәсәнов // Сафлану. *Күңел яктыра, күзләр нурланып китә, хәтта сулган-саргайган йөзләргә алсулык сирпелә.* И.Салахов

8) *күч.* Матураеп китү, якты, матур булып тоелу; матур булып күренү. *Кайгырма син, иркәм, мин кайтырмын. Тик көнебез генә яктырсын.* Ә.Ерикәй. *Мин Агыйделгә, аның аръягындагы тугайга, урманга карыйм, караган саен карыйсым килә, торган саен дөнья яктыра, төсмерләргә байый бара.* М.Маликова

**Яктыра бару** Аз-азлап, акрынлап яктыру. *Һаман саен балкый, яктыра барган нурлар да тәэсир итми, җирдә аунаган мәһабәт, батыр ирләр селкенергә һич уйламый иде...* В.Имамов

**Яктыра башлау** Яктыру билгеләре күренү, яктырырга тотыну. *Без иртән яктыра башлауга килеп утырабыз да, һәркайсыбыз сабакны кабатларга, үзебез аңламый торган китап сүзләрен ятларга тотынабыз.* Г.Бәширов. *Шулайрак булып чыкты да: сәгать унберне узып, яктыра башлауга, бригада таныш урынга килеп җитте.* И.Хуҗин

**Яктыра төшү** Бераз яктыру; тагын да ныграк яктыру. *Кызларның көләч йөзләре тагын да яктыра төшә, көлүләре тагын да дәртлерәк яңгырый.* Г.Әпсәләмов. *Кызының тынычландырырга теләп әйткән йомшак сүзләреннән ананың йөзе тагы да яктыра төште.* И.Нәбиуллина

**Яктырып бетү** Тәмам яктыру. *Бөтенләй яктырып беткәч кенә йокыга киткәнмен.* Н.Әхмәдиев. *Бу иртәне*

*алар тәмам яктырып беткәнне көтмәскә, иртәрәк кузгалырга булдылар.* А.Хәсәнов

**Яктырып җитү** Тәмам, тулысынча яктыру. *Бүген дә бәрәнге утыртырга яктырып җитмәстән үк чыктылар, Сәрвия смена алыштырырга киткәнче әллә ни үрчетә алмасалар да, алга китеш барыбер булыр.* М.Хуҗин. *Кышкы иртә тиз генә яктырып җитә алмый.* Ф.Яхин

**Яктырып калу** Берәр вакыйгадан, тәэсирдән соң яктырган хәлгә килү. *Өй һавасы сафланып, яктырып калды.* А.Хәлим. *Аяз көнне кешенең уйлары югарырак, хыяллары биегрәк була, зәңгәр күккә карап торган чакта ул дөнья мәшәкатьләреннән беразга булса да арынып тора, чистарынып, күңеле яктырып кала.* Р.Вәлиев

**Яктырып килү** Акрынлап яктыра башлау. *Инде таң аткач, тәмам яктырып килгәндә генә, алар икесе дә изрәп йоклап киттеләр.* А.Хәсәнов. *Көн яктырып килә иде күрәсең, тәрәзә пәрдәләре аша йомшак яктылык саркый.* М.Маликова

**Яктырып китү** Бераз яктыру. *Фәридун абзый аны күрмәмешкә салына, тик йөзе яктырып киткәнен яшерә алмый, канәгатьләнеп, тамагын кырып куя.* В.Юныс. *Алар чиста, пакь булган чакта гына өй эченә җылы якты нурлар үтеп керә, хуҗа кешеләрнең дә, башкаларның да күңелләре яктырып китә.* А.Мансуров

**Яктырып кую** Кинәт яктыру. *Су өсләре, эңгер-меңгерләнеп торган каршы як ярлар гөлт итеп яктырып куйды.* М.Хәсәнов. *Көтмәгәндә малайның зиһене яктырып куйды.* А.Хәлим

**Яктырып тору** Яктырып күренү; яктыру үзлеге булу. *Күләгәле урыннарда су кап-кара, кояшлы урыннарда яктырып тора.* Г.Әпсәләмов

**ЯКТЫРЫЛЫШ** *и.* 1) Нәрсәдән дә булса төшә торган тигез яктылык; ялтыравык. *Яктырылыш дәрәҗәсе*

2) *күч.* Яктырту (*7 мәгъ.*) күренеше. *Аның башлангыч иҗатында геройның азатлык һәм мәхәббәт идеалы традицион-трагик яктырылышында калды әле.* Г.Халит. *Бу чара матбугатта, радио-телевидениедә дә яктырылыш тапты, һәм ул еш кына «Татар мәдәнияте көннәре» дигән бәя дә алды.* Х.Миңнегулов

**ЯКУТ** I *и. гар.* **1.** Рубин, сапфир һ.б.ш. кебек, кызыл, зәңгәр һәм сыек зәңгәр төсләрдәге кыйммәтле асылташларның гомуми атамасы; *русчасы:* **яхонт**. *Алар кояш нурларында якут күк кызарып утыралар.* Гали Рәхим. *Ул өлгеләргә энҗе, кызыл якут, фирүзә кебек кыйммәтле асылташлардан күзләр уелган.* М.Әмирханов

**2.** *с. мәгъ.* Шул ташка охшаган, шуның төсендәге. *Безнең якның чияләре кебек, якут җимеш сарган ботакны!* Р.Фәйзуллин. *Тик ай түгел, якут йолдыз Куелган очларына.* И.Сабиров

**ЯКУТ** II *и.* Телләре төрки телләр семьялыгына караган, шаманчылык һәм православие динен тота торган, күпчелеге Якутиядә яшәүче төп халык атамасы (үзатамалары – саха) һәм шул халыкның бер вәкиле. *Гагауз телендә шор, хакас, алтай, якут телләренә генә хас бик борынгы үзенчәлекләрнең дә саклануы халыкның үтә катлаулы һәм озын үсеш юлы узуы хакында сөйли.* Т.Әйди. *Татар, башкорт, чуваш, якут һ.б.ны милли азчылык дип кабул итеп булмаячак, алар үз территорияләреннән тыш та төп халык булып торалар.* Р.Хәкимов

**ЯКУ́ТЧА** *рәв.* **1.** 1) Якут телендә. *Аннары, акыл өйрәткән бер төс белән, якутча нидер әйтте.* Н.Ихсанов. *Кызылда яшәгәндә, ана телем – татар теленнән кала, тыва, урыс, казах һәм якутча, ягъни дүрт телдә сөйләшергә өйрәндем.* Безнең гәҗит

2) Якутларга хас булганча, якут халкындагыча. *Якутча тәрбияләү*

**2.** *с. мәгъ.* 1) Якут телендәге. *Узган гасырның 90 нчы елларында беренче якутча хатын-кызлар журналы «Далбар хотун»ны (сүзгә-сүз тәрҗемәсе: «Чын йөрәктән кабул итүче хатын-кыз») оештыруда катнаша, аның баш мөхәррире була.* Кызыл таң. *Якутча шигырь*

2) Якут халкына караган, шуңа хас булганча. *Якутча туй*

**ЯКЧЫЛЫК** *и. а.х.* Терлекчелекнең яклар үрчетү тармагы. *Якчылык продукциясе*

**ЯКШӘМБЕ** *и. фар.* Атнаның җиденче көне; базар көн. *Бигрәк тә якшәмбе көннәрдә, бүтәннәргә дуслары, кардәшләре күчтәнәчләр алып килгән чакларда, аңа ямансу була.* Г.Әпсәләмов. *Бу хәл атна саен, якшәмбе җиткән саен кабатлана.* А.Әхмәтгалиева

**ЯКЫН** *с.* **1.** 1) Билгеле бер җирдән еракта урнашмаган, арасы ерак булмаган, шушы тирәдәге, тиз генә барып җитәрлек; *киресе:* **ерак**. *Фронтка якын шәһәрдә урынсыз сорауга кешеләр бүтәнчә җавап бирә алмауларын ул шунда ук төшенеп алды.* Г.Әпсәләмов. *Мондый якын җирдән икенче бер фатир табасыңмы әле, юкмы.* Р.Рахман

2) Тиздән булырга тиешле, тиз арада булачак; гомумән, вакыт аралыгы зур булмаган. *Мин баламны якын көннәрдә бирәдән килеп алачакмын.* Д.Салихов. *Заман коточкыч тизлектә үзгәреп тора, һәм, бәлки, якын киләчәктә дәвалау мөмкинлеге дә ачылыр.* М.Кәбиров

3) Турыдан-туры кан кардәш булган, туган. *Гаиләң, балаларың, якыннарың бар бит әле...* А.Хәсәнов. *Бу кичтә мин, якыннарым белән генә хушлашып, бу авылдан китеп бардым.* А.Нәҗми

4) Тыгыз дуслык мөнәсәбәтендә булган. *Билгеле, минем йөз сум акчам юк, әмма бик якын ике дусым бар иде.* А.Шамов. *Ә менә институтта укуының беренче көннәреннән үк, әлеге шул казылык аркасында группадашлары арасында бик тә тиз үз кеше, якын кеше булып китте Фәләх.* В.Нуруллин

5) Кадерле, үз. *Туган-үскән илнең җанга никадәр якын, кадерле, изге икәнен беләсең килсә, менә алардан гына сора.* А.Хәсәнов. *Йөрәгем нииндидер күптән таныш һәм бик тә якын әйберен тапкандай тибрәнеп куйды.* А.Мансуров

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Ерак түгел, арасы ерак булмаган килеш; монда гына, янәшәдә, терәлеп үк. *Әгәр инде оя-өн корган, анда балаларың калган урманга бик якын торган авылларга төшеп, аларның сарык бәрәннәрен еш ташый башласаң, ул авылларның агайлары, түзәләр-түзәләр дә, беркөнне сәнәкләр, күсәкләр белән коралланып, авыл өстендәге урманга ябырылалар.* А.Хәсәнов. *Ә чегән таборын әйтмим дә: бигрәк якын урнашкан икән, әгәр дә сузылсаң, валлаһи менә, кул белән кагылырга була сыман.* И.Диндаров

2) Кемгә яки нәрсәгә дә булса бик аз гына ара калырлык итеп. *Аның кара кашларының бер-берсенә тоташырдай якын торулары, шомырт кара күзләр, икегә аерылган түгәрәк ияк, киң маңгайга төшкән кара чәчләр – барысы да, барысы да йөрәктә җуелмаслык эз калдырдылар...* А.Алиш. *Хафиз бабайның күзләре кысылган, ул, учын авызына якын китереп, кет-кет көлә иде.* А.Гыйләҗев

3) Яхшы мөнәсәбәттә; туганнар кебек. *Ике гаиләнең балалары – без, туганнардай якын булып, әле беребезнең, әле икенчебезнең гаиләсендә ашап-эчеп, кунып калган чаклар да була иде.* А.Нәҗми

**3.** *хәб. функ.* 1) Арасы аз булу; ерак булмау. *Суның кимегән чагы булганлыктан, яр бик якын.* Г.Әпсәләмов. *Терсәк якын, тик кем генә аны тешли ала...* А.Әхмәтгалиева

2) Тиздән булу, тиз арада булу, килү. *Төн бик якын.* А.Хәлим

3) Бик кадерле, үз булу. *Сез дә миңа бик якын.* А.Хәсәнов. *Укытып чыгарган студентларым да, нәкъ балаларым кебек үк, һәммәсе дә бик якын.* Аманулла

4) Охшаган булу; ниндидер сыйфатлар, билгеләре белән тартым булу. *Бу җәһәттән ул халыкчанлыгы, ихласлыгы, моңы белән әсир иткән Илһам Шакировка бик якын.* И.Юзеев. *Уйгур теле – безгә тугандаш, татар теленә бик якын.* Г.Гомәр

**4.** *и. мәгъ.* 1) Туган, кардәш кеше; әтиәни, балалар кебек иң кадерле кешеләр. *Ул, якыннарына җиңелрәк, турырак юллар насыйп булуын теләп, һәр сулышында Аллаһка ялвара иде.* Д.Булатова

2) Дус, иптәш. *Бу серне, якыннарымның берсенә дә әйтмичә, мин сакларга тиеш бит әле.* А.Хәсәнов

3) Сөйгән яр, ир яки хатын. *Ике шатлыгым бар иде: әнкәй карчык та Вәзирә якыным.* Ә.Гаффар. *Яз иде... Берәүнең якыны Урманнан чәчәкләр китерде.* Д.Гыйсметдин

**5.** *бәйл. функ.* 1) Охшаш, охшаган, тартым, кебек. *Гайникамал апа ифрат та әрнүле, елауга якын көй-моң белән мөнәҗәт әйтте.* М.Хәсәнов. *Ул акылдан шашуга якын бер гамьсезлек һәм өметсезлек кичерде.* Н.Фәттах

2) Нәрсәнең дә булса зурлыгы, ераклыгы, озынлыгы билгеле чамада булуын белдерә; диярлек, чамасы. *Йортның төп өлешендә егермегә якын гаилә яши.* З.Хәким. *«Мәкам» бу очракта ислам традицияләре белән бәйле көйле сөйләмгә якын уку ысулын белдерә.* Г.Макаров

◊ **Якын арада** Шушы көннәрдә, тиздән. *Кәримә көтте, үзе белән якын арада булачак зур үзгәрешкә алдан ук әзерләнде.* З.Хөснияр. *Ашыгудан файда юк, барыбер якын арада яңгыр булмас, диләр...* Г.Гыйльманов. **Якын да җибәрмәү** Нәрсә дә булса эшләргә, кая да булса барырга рөхсәт итмәү. *Моннан соң нәшриятка якын да җибәрмәүләре мөмкин бит инде Шәрәфне.* Л.Ихсанова. *Шулай да берсе түзмәде, күршесенең колагына әйтеп куйды: «Бала тәрбияләргә безне якын да җибәрмиләр».* Р.Батулла. **Якын да килмәү** 1) Тыңларга да, белергә дә теләмәү, кемнең дә булса фикере белән һич килешмәү, риза булмау. *Беркөнне Шәйхетдинов барып сөйләште, якын да килмиләр, ди.* Т.Гыйззәт. *Ул бит кызу канлы, якын да килми, шул Бурлар нәселенә якын барасы булмасын сеңлем Нурания, ди.* Р.Камал; 2) Охшамау, охшашлык бөтенләй булмау. *Ул күп яза, берберсенә якын да килмәгән төрле жанрларда иҗат итә.* Р.Миңнуллин. *Матур кинолардагы хастаханәләргә якын да килми безнең бала тудыру йортларындагы шартлар.* С.Камалова; 3) Туры килмәү, килешмәү. *Сәнгать дигән сәер, сирәк очрый һәм хуҗасының табигатенә якын да килми торган исемне аны тәрбияләп, багып үстергән әбисе куша.* Т.Галиуллин. *Озын чәч, үкчәле, озын кунычлы күн итек, ертык джинсылар – гомумән, татар эстрадасына якын да килә торган түгел иде ул стиль.* Э.Фатыйхова; 4) Ярамау, сыймау (кием тур.). *Элек кигән итәкләрем хәзер якын да килми.* Кызыл таң. **Якын да китермәү** 1) Нәрсәгә дә булса катгый каршы килү. *Әнигә [акча] бирмәкче булган идем, якын да китерми.* М.Җәлил. *Бу хакта сүз кушасың икән, ул сиңа әллә нинди сылтаулар табып, якын да китерми.* К.Миңлебаев; 2) Читләшү, чит итү, үз итмәү. *Чибәр, акыллы кызны сыйныфташлары якын да китермәделәр.* М.Вәлиев. **Якын килү** 1) Кем белән дә булса яхшы мөгамәлә урнаштыра алу, уртак тел табу. *Фәтхия янына беркем дә якын килә алмады, аның янында беркем дә артык хәрәкәт ясамады.* М.Мәһдиев. *Ничек анда сыйды икән әби, Хәмидә апага якын килерлек түгел иде бит?* Р.Габделхакова; 2) Нинди дә булса эшкә, мәсьәләгә һ.б. билгеле караштa булу. *Ул Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институты белән берлектә эшләнә, камилләштерелә, ягъни татар халкының милли үзенчәлеге проблемасына фәнни яктан якын килenә.* Казан утлары; 3) Билгеле мөнәсәбәт күрсәтү. *Менә ни өчен без бу мәсьәләгә кабат-кабат уйлап якын килергә тиеш.* Т.Миңнуллин. *Башта кадрлар сайлап алуга җитди якын килде.* Т.Нәҗмиев. **Якын көннәрдә** *к.* **якын арада**. *Якын көннәрдә күп нәрсәләр ачыкланырга тиеш.* Н.Акмал. *Якын көннәрдә, боерган булса, туган якларны бер урап кайтырга, дигән уем да бар иде.* Р.Мөхәммәдиев

**ЯКЫНАЕШУ** *ф. урт. юн. к.* **якынаю**. *Ияләре дә якынаешкан – бик ихлас гәпләшеп баралар!* Ш.Галиев. *Аларны ишектә күргәч, Җиһангировның маңгаена сизелер-сизелмәс сызылган җыерчыклары, кәкрәешеп, бер-берсенә якынаештылар.* Ф.Садриев

**Якынаешып алу** Бик тиз якынаешу; аз вакытка якынаешу. *Иптәшләре белән шулай якынаешып алгач, Мусаның күңеле шактый ачылып китте хәзер.* Ш.Маннур

**Якынаешып бетү** Тәмам якынаешу; бик нык якынаешу. *Кыскасы, бик дуслашып, якынаешып беткән идек инде без соңгы көннәргә.* Кызыл таң

**Якынаешып китү** Билгеле моменттан башлап якынаешу. *Шәһәр җире булып, үзара аралашып яшәсәк, бәлки, синең белән якынаешып китәр идек.* К.Тимбикова

**ЯКЫНАЙТУ** *ф.* 1) Нәрсәнедер якын китерү; ераклыкны, араны киметү. *«Алыгыз балдагыгызны!» – диде Нәҗип, учын аңа таба якынайтып.* А.Гыйләҗев. *– Мәктәбебез өскә ава, менә карагыз, менә! – ул берәм-берәм сурәтләрне түрәнең йөзенә якынайтты.* Н.Гыйматдинова

2) Үтәү яки үтәлү вакытын киметү; тизләтү; кирәкле вакытның тизрәк килеп җитүенә тәэсир итү. *Яшьтәшләре яу кырында сугышып йөргәндә, Нәҗип аларның балаларына белем бирә, аларны тәрбияләп, җиңү көнен якынайта.* Л.Шәех // Билгеле вакытның килгәнен көтү, вакыт уздыру. *Ә үзенең җылы өендә яту белән йокыга киткән канәгать чырайлы Мидхәт Хәсьянов, гырлый-гырлый, таңны якынайта иде.* Н.Әхмәдиев

3) Үзе белән якыннан аралашу мөмкинлеге бирү; якыннан аралаша торган кешеләре арасына кертү. *Берлек рәисе итеп сайлангач та, аны үземә якынайтырга, кайбер вакытларда аңа таянырга теләдем.* Т.Миңнуллин. *Шул юл белән ул кешеләрнең күңеленә үтеп кергән, аларны үзенә якынайткан.* А.Вергазов

4) Бер-берсенә җәлеп итү, якын рухи мөнәсәбәт урнаштыру, бәйләү. *Юл йөрү кешене кешегә якынайта, юл сәфәре кешене кешедән читләштерә дә.* Р.Батулла. *Кыска гына вакыт эчендә еш аралашу, бер-берсенең хәленә керү, уй-фикерләрне, дөнья мәшәкатьләрен уртага салып сөйләшү аларның өчесен дә бик нык якынайтты.* З.Мәхмүди

5) Нәрсә белән дә булса кызыксындыру, нинди дә булса юлга, юнәлешкә кертеп җибәрергә этәргеч булу. *Аларның бер-берсенә булган игътибарын,*

*ихтирамын тою, азан тавышы яңгырагач, шыпырт кына намаз укып килүләрен күрү дә соклану хисен тудырып кына калмады, әлеге кешеләргә, дингә якынайтты.* Ватаным Татарстан

6) Нәрсәгәдер бик охшаш, якын итү; охшату; яраклаштыру. *Бу сүзләрдән күренгәнчә, китап балаларга аңлаешлы, гарәп-фарсы алынмалары аз, әдәби телгә якын булган Казан арты сөйләшенә якынайтып язылган.* С.Сәмитова. *Әсәрнең телен халык теленә якынайтасы һәм әдәби яктан эшкәртәсе бар.* Кызыл таң

7) Теге яки бу билгеләре, үзенчәлекләре белән бер-берсенә охшаш итү. *Татар һәм мари телләрен якынайта торган тагын бер күренеш – әлеге телләрнең шактый киң территориядә таралып урнашкан булуы.* М.Саттарова

**Якынайта бару** Торган саен күбрәк якынайту. *Тормышта күбрәк яшәгән саен, күңелемдә өлгереп килгән хисләр мине сиңа якынайта бара.* Н.Хәсәнов. *Сайдәнең карынында тибенеп яткан җан-бәгырь кисәге бу ике табигать баласын көннән-көн бер-беренә якынайта бара.* Г.Гыйльманов

**Якынайта башлау** Якынайтырга керешү. *Шул вакытта койрык бераз уйнап алды, ләкин ул бер минутка да сузылмагандыр, самолёт, тотрыкланып, болытлар арасына кереп чумды, һәм һәр минут безне Бөгелмәгә якынайта башлады.* Н.Әхмәдиев. *Ике имән бармагын тырпайтып, бер-беренә төзәп, якынайта башлады.* Р.Батулла

**Якынайта бирү** Бернигә дә карамый якынайтуны дәвам итү. *Әлегә, әлхәмделиллаһ, аякларыннан зарланмый, күктә бәхет вәгъдә иткән йолдызларга карый-карый, авыл белән ике араны якынайта бирә.* Н.Әхмәдиев

**Якынайта төшү** Бераз якынайту; тагын да ныграк якынайту. *Баланың дөньяга килүен көтү аларны якынайта төште.* Н.Әхмәдиев

**Якынайтып бетерү** Бик нык якынайту; тәмам якынайту. *Хатлар, күрәсең, юкка гына йөрмәгәннәр, вазифаларын әйбәт башкарганнар – безне якынайтып бетергәннәр.* Ә.Маликов. *Әйе, ике шәһәр арасын якынайтып бетердем инде.* Тамаша

**Якынайтып җибәрү** Якынаерга этәргеч бирү, сәбәп булу; бераз якынайту. *Уртак шатлык аларны тагы да якынайтып җибәрде.* Ф.Яруллин. *Әмма баштагы мәлдә, әле әдәби карашлар берлеге пәйда булганчы, Рөстәм белән мине, икебез ике бүлектә укуга карамастан, француз теле дәресләре якынайтып җибәрде.* Н.Гамбәр

**Якынайтып тору** Вакытлыча якынайту; даими якынайту. *Чынлап та, Үзәктәге югары даирә җитәкчеләренең һәммәсе белән танышлыгы булуга да карамастан, Сталин белән Мирсәетне байтак кына вакыйгалар һәм икесе генә белгән серләр якынайтып тора иде.* Р.Мөхәммәдиев. *Ниндидер күренми торган җеп безне бәйләп, якынайтып тора, бусы – бәхәссез.* Туганайлар

**ЯКЫНАЮ** *ф.* 1) Кемгә яки нәрсәгә дә булса якынрак килү. *Бүреләр якынайганнан-якыная, аралары күп дисәң бер ыргым калгандыр...* М.Әмирханов. *Менә ул, атлый торгач, бөтенләй якыная.* К.Җәмит

2) Кыскару, кимү (ара, юл тур.). *Ара коточкыч тизлек белән якыная иде.* И.Хуҗин. *Ерак юл якынаер – канатлар талмаса, яктылык нурыннан азакка калмаса...* М.Мирза

3) Җитү, килү (вакыт, хәл, вакыйга тур.). *Бергә йөрегез, балалар, китәр көннәрегез дә якыная бит.* Г.Галиева. *Көн артыннан көннәр үтә, Салкын көз якыная. Кояш та кыздырмый башлый, Яңгырлар да ешая.* Р.Вәлиева

4) Кадерле, үз булып китү. *Дуслаштылар, әмма күңелләре белән бер-берсенә артык якыная алмадылар.* М.Маликова. *Мондый мөнәсәбәт аша табиб авыруга якыная, аның газиз бер кешесенә әверелә.* Г.Гыйльманов

5) Охшашлану, уртак сыйфатлар барлыкка килү яки арту, аерымлыклар кимү. *Диалектлар әдәби телгә якыная*

6) Көчәю, элеккегә караганда яхшырак, ачыграк ишетелү (тавышлар тур.). *Быргы тавышы якыная.* Н.Фәттах. *Җыр якыная, көчәя.* Л.Лерон

7) *күч.* Кем белән дә булса якын, дустанә мөнәсәбәткә керү; дуслашу. *Без бик якынайдык, бер-беребезгә тәмам ияләштек...* Ә.Еники. *Без аның белән шул чорда бик якынайдык, дуслаштык.* А.Расих

8) *күч.* Иман ныгый бару; Аллаһка ышану арту. *Әле бүген дә колагымда әнкәемнең «Манарага менгән кеше Аллаһы Тәгаләгә якыная» дигән сүзләре яңгырап тора сыман.* Р.Вәлиев. *Безгә бер-береңне сөю, Аллага якынаю кирәк.* З.Мәхмүди

9) *күч.* Берәр нәрсәгә омтылу, билгеле бер өлкәгә, юнәлешкә игътибар арту. *Алар гаилә белән ураза тоталар, дини бәйрәмнәрне билгеләп үтәләр, балаларының дингә якынаюын күреп сөенәләр.* Туган як

**Якынаеп бетү** Бик нык якынаю; шактый якынаю. *Авылга кайтып җиткәндә, алар тәмам якынаеп беткәннәр иде инде.* Ф.Яруллин. *Кешеләр торабара бер-берсенә якынаеп бетәләр, ә без һаман ераклашканбыз түгелме?* Ф.Җамалетдинова

**Якынаеп җитү** *к.* **якынаеп бетү**. *Шагыйрьгә якынаеп җитмәде кыз, тукталды.* М.Хуҗин. *Бу вакытта депутат, кояшка кадәр чөелгән биеклегеннән күптән авышып, бозга каткан елан җиргә якынаеп җитеп килә иде.* Ф.Яхин

**Якынаеп калу** Якынайган хәлгә килү. *Бермәлне ул кызга шактый якынаеп калды.* Н.Фәттах. *Чыннан да, ул берничә мәртәбә максатына ирешүгә бик якынаеп кала.* Ф.Хатипов

**Якынаеп килү** Акрынлап якынаю; якыная башлау. *Бәхетенә каршы, егеткә дачалар ягыннан якынаеп килүче машина уты күренде.* В.Нуруллин

**Якынаеп китү** Көтмәгәндә якынаю; нинди дә булса сәбәптән яки билгеле бер вакыттан соң якынаю. *Хәмит дигәннән, өч-дүрт ай бергә аралашсак та, якынаеп китә алмадык без аның белән.* А.Гыйләҗев. *Ләкин геологлар арасыннан берсе – зифа буйлы, ак йөзлесе – күңелгә якынаеп китте бит.* М.Маликова

**Якынаеп кую** Тиз арада якынаю. *Була икән шул моның кебек гайре табигый хәл дә: башта кешеләр, үзләре дә аңламаган ниндидер бер сукыр кодрәткә буйсынып, әллә ничек кенә якынаеп куялар, аннары инде бер-берсен аңларга, белергә тырышалар...* Ә.Еники. *Ул балкыганда, алсу нур белән читләнгән болытлар, ерактагы офыклар, күк гөмбәзе сиңа таба якынаеп-якынаеп куя.* Ф.Садриев

**Якынаеп тору** Хәзерге вакытта якынаю; якын булып күренү; вакытлыча якынаю. *Ара бераз якынаеп тора да тагын ерагая.* Кызыл таң

**Якыная бару** Торган саен якынаю. *Аның саен Г.Рәхим әдәбият, фән дөньясына якыная бара.* М.Мәһдиев. *Чатырларга якыная барган саен, аның әллә нишләп хәле бетә, тыны кысыла шикелле тоелды.* Н.Фәттах

**Якыная башлау** Якынаерга тотыну. *Гаҗәп, Эдуардның вертолёты да, гүя аны эзәрлекләгәндәй, зур тизлек белән машинага якыная башлады.* А.Гыймадиев. *Чит-ят кешеләр якыная баш-*

*ласа, барлы-юклы тавышын кызганмыйча, өргән булып, җан әсәре барлыгын белдерә.* Г.Гыйльманов

**Якыная бирү** Бернигә карамый якынаюын дәвам итү. *Сөйләшкән саен Леон безгә таба якыная бирә иде.* М.Юныс. *Теге яшь-җилкенчәкләр безгә таба һаман да якыная бирделәр.* Ф.Яхин

**Якыная төшү** Бераз якынаю; тагы да ныграк якынаю. *Мунчага якыная төшкәч, Закир абый туктап бераз тыңлап торды, әле бер яктан, әле икенче яктан чүгәләп карады да авызын каплап көлергә керешә.* Г.Бәширов. *Якыная төшкәч, бу милиционерны таныгандай да булды.* Д.Бүләков

**ЯКЫНДА** *рәв.* 1) Янәшәдә, бу тирәдә; берәр кешедән яки әйбердән ерак түгел урында. *Ак чишмә дә якында гына булырга тиеш, күңел дертләп китте.* Н.Нәҗми. *Бормаланып-уралып елга агып ята, якында урманы, тавы, чишмәләре, иген кырлары – барысы да бар.* З.Мурсиев

2) Якын көннәрдә, шушы көннәрдә, тиздән; якын киләчәктә (вакыт җитү тур.). *Ләкин якында гына торган җиңү аларны һәрчак дәртләндерә, һәм алар, сугышны үзләре файдасына тәмамлар өчен, көчләрен кызганмыйлар.* З.Зәйнуллин. *Шул чакта аның зиһене бер нәрсәне эләктереп алды: бу шатлык юкка түгел, аның бөтен барлыгын рәхәтләндерәчәк шушы ләззәт бик якында гына.* Ф.Садриев

**ЯКЫНДАГЫ** *с.* 1) Якын урындагы, янәшәдәге, якын тирәдәге, торган урыны ерак булмаган. *Якындагы акчарлак кабартма кисәген шунда ук күреп алды һәм очып барган уңайга эләктереп алып йотып та җибәрде.* Н.Каштанов. *Алар үз балаларымдыр сыман тоелды, һәм мин, якындагы киосктан кәнфит алып, һәрберсенә өләшеп чыктым.* М.Кәбиров

2) Тиз арада була торган; чираттагы; агымдагы; озакламый булачак. *Якындагы идарә утырышында график расланды.* Н.Әхмәдиев. *Шулай да, иманым камил: якындагы елларда Уфа, гасыр башындагы кебек, яңадан татарның мәдәни, әдәби үзәкләренең берсенә әйләнер.* Р.Миңнуллин

**ЯКЫ́Н ИТҮ** ф. 1) Якын итеп урнаштыру. *Йортларны бер-берсенә бик якын итеп төзергә ярамый*

2) Якынайту, якын китерү. *Ерак араны якын итәргә автобус яки үз машинасы булыша хәзер.* Хезмәт даны

3) Ераксынмау, ерак санамау. *Мин, ерак юлны якын итеп, үзем килдем.* Т.Миңнуллин. *Бәби чиреннән котылгач та, ерак юлны якын итеп, әнкәемнең тизрәк килеп җитүен, үз йортлары белән торучы танышларыбызга бәби мунчасы ягып, мине дә шулай сыйпыйсыйпый юындыруын исемә төшерәм.* Э.Шәрифуллина

4) Үз итү, үз күрү; хөрмәт итү. *Кайнаталары аны үз балаларыдай якын итәләр.* А.Тимергалин. *Әллә инде әбекәйнең йомшак тавышы, әллә якын итеп «балам» диеп эндәшүе барысын да сөйлисе килү теләген уятты.* А.Мансуров

**ЯКЫНЛАТУ** *ф. диал. к.* **якынайту**. *Жомагыл сирәк кенә сакал-мыек баскан йөзен Сәйфуллага якынлатты.* З.Зәйнуллин. *[ә]дә иреннәрнең [а]га карaганда якыная һәм җәелә төшүе дә [ә] авазын [и]гә якынлата.* Ш.Асылгәрәев

**ЯКЫНЛА́У** *ф. диал. к.* **якынаю**. *– Уйла, – ди Көз. – Кышлар якынлый!* С.Гәрәева. *Бәй, аннан карыйм: гомер үтә, исән йөреп ятам, яшь кырыкка якынлый.* Д.Булатова

**Якынлап бару** Вакыт үткән саен ныграк якынлау. *Чокырның тирәнлеге кендеккә үк якынлап бара түгелме?* А.Хәлим

**Якынлап килү** Әкренләп якынлау. *Инде кайтыр чагы якынлап килә иде.* Г.Ибраһимов. *Инде азакка якынлап киләбез...* З.Мифтахов

**Якынлый башлау** Якынлауга таба бару. *Иртәнге салкын белән басуны бер әйләндерәләр дә, кояш кыздыра, төш якынлый башлагач, көтүне су буена «туклау»га төшерәләр.* Г.Ибраһимов

**ЯКЫНЛАШТЫРУ** *ф.* 1) Нәрсәгәдер якынрак урынга күчерү; ниндидер ике нәрсәнең арасын киметү. *Әтисе кулларын рәсемгә якынлаштырды: – Кызым, кызым! Кояшыңның нурлары кулымны җылыта.* Г.Сабитов. *Агай иплән кенә җиңен өскәрәк сыпырып куйды, мылтыктан төзәгәндәй, сул күзен йомып, барабан таягыдай сөякчел бармакларын әкрен генә көндәшенең борын төбенә якынлаштырды.* Д.Гыйсметдин

2) Берәр нәрсәнең үтәлү срогын, җитү вакытын алгарак күчерү. *Эх, романың кулына китап итеп тоту бәхетен тату көнен тизрәк якынлаштырасы иде...* М.Хуҗин. *Ә сәгать ашыга-ашыга Яңа елны якынлаштыра.* Р.Юсупова

3) Охшаш итү. *Гүзәл табигатьнең дошманы – кеше үзе, дигән фикер якынлаштыра ике әсәрне.* Әдәбият. *Хәзерге заманның кайбер яшьләрендәге традицияләргә җиңел караш аларның шәхес буларак үсешен тоткарлап, маймыл бабаларына якынлаштырса, өлкәннәрнең хәтерсезлеге соңрак килүче буыннарда – балаларында, оныкларында туганлык элемтәләрен яңартуга, тарихны аңлауга омтылышны көчәйтә.* М.Вәлиев // Нәрсәгә дә булса охшату, шуның кебек эшләү. *Ул кайчандыр төрки телгә якынлаштырып язып алынган.* Р.Әхмәтьянов

4) *күч.* Мөнәсәбәтләрне тагын да яхшырту; якынайту. *Шул авыр язмыш аны Гөлбану белән якынлаштырды; шул аны яшь бикә, яшь килен ягыннан Әремтел Сабирага каршы калкан булып барырга эчтән-күңелдән омтылдырды.* Г.Ибраһимов. *Сезнең килү безне бер-беребезгә якынлаштырды.* Г.Кутуй

**Якынлаштыра бару** Акрынлап, азазлап якынлаштыру, торган саен ныграк якынлаштыру. *Хәлимдәге сабырлык һәм аның башын иеп утыруы җыелыш рәислеген үз кулында шытырдатып тоткан «тәрбия директоры»ның көчен тагын да арттырып, егетнең һәлакәтен якынлаштыра барды.* Ф.Яхин

**Якынлаштыра башлау** Якынлаштырырга тотыну. *Без, башкортның сатылган киң яланнарыннан, анда килмешәк салган зур сарайларыннан, савым бияләренең азаюыннан, борынгы куәтле кымызларның бетүләреннән киләкилә, сүзне милли көйләр мәсьәләсенә якынлаштыра башладык.* Г.Ибраһимов

**Якынлаштыра төшү** Берникадәр якынлаштыру; тагы да якынлаштыру

**Якынлаштырып бетерү** Бик нык якынлаштыру. *Уртак эш безне якынлаштырып бетерде.* Идел

**Якынлаштырып җибәрү** Бераз якынлаштыру, якынлаштыра башлау. *Каһарманнарының биографияләрен, сөю-сөешү тарихларын ачуда шигъри романнарда элегрәк табылган хат язышу, мәктүб алышу, тиешле җиргә барып кайту, --- озын диалоглар, тыгыз егәрле прозаик сөйләмнәр кабул ителгән традицияләргә якынлаштырып җибәрәләр.* Р.Харис. *Уртак максатлар үйтойгыларны, фикерләү төрләрен ничектер якынлаштырып җибәрде.* Әдәбият

**Якынлаштырып килү** Электән үк, әзлекле рәвештә якынлаштыру. *Бүгенге көндә исә Сармашбаш авылында моннан ике ел элек башланган «Саф су» программасы буенча су кертү эшен ахырына якынлаштырып килә.* Зәй офыклары

**Якынлаштырып кую** Кинәт якынлаштыру; тиз арада якынлашкан хәлгә китерү. *Учларын учка куеп, сулышларын тоеп, бер кәлимә сүз алышу насыйп булмаса да, ниндидер илаһи, күкләрдән иңгән көч бу ике олуг шәхесне бер-берсенә бик якын туганнардай, чын дуслардай мәңгелеккә якынлаштырып куйган.* Т.Галиуллин

**Якынлаштырып тору** Һәрвакыт, гел якынлаштыру; вакытлыча якынлаштыру

**ЯКЫНЛАШУ** *ф.* 1) Кемгә яки нәрсәгә дә булса якын килү, якынаю. *Ә каршы ярдан асылмалы күпергә таба солдат егет якынлаша.* Г.Әдһәмова. *Ул балалар өстенә күз ташлап елмая да, бөтен барлыгыннан затлылык бөркеп торган искиткеч килешле гәүдәсен туры тотып, укытучы өстәленә якынлаша.* Д.Каюмова

2) Вакыты килү, җитү, булырга тору. *Кибеткә барасым бар иде, намаз вакыты да якынлаша...* А.Гадел. *Рәйсәсенең туган көне якынлаша, шәһәрдән күлмәк-фәлән алып кайтырга кушып, үткән юлы биш йөз сум акча биреп җибәргән иде.* Д.Булатова

3) *ялг. к.* **якынаю** (*7 мәгъ.*). Кадерле, үз кеше булып китү; дуслашу. *Йөрәк тибешеңне тыңлап, ерак хыялыма ашам, синнән ераклашкан саен, бәгърем, сиңа якынлашам!* И.Юзеев. *Җәй көне мин аларга тагын да якынлаштым.* Сөембикә

4) Билгеле санга җитеп бару, берәр микъдарга тула язу. *Аның эш арасында чыгарган китаплары өч дистәгә якынлашты.* Т.Нәҗмиев

**Якынлаша бару** Торган саен ныграк якынлашу. *Ләкин күпме генә тыныч булырга тырышсам да, теге төшкә якынлаша барган саен, сагаюым артканнан-арта бара.* Р.Мөхәммәдиев. *Тагын читкә таба тартылам – файдасыз, аның саен Фатыйма апага ныграк кына якынлаша барам, чарасызлыктан кычкырып елыйсым килә, күзләрдән яшь атылып чыга.* З.Хөснияр

**Якынлаша башлау** Якынлашырга тотыну. *Җәүдәттән алдарак торган Габдрәхим лап-лоп атлап сафтан чыкты да атка якынлаша башлады.* З.Зәйнуллин. *Салкын көзләр якынлаша башлагач, бәпкәләр үскән, ныгыган саен, күңелемне авыр сагыш баса.* Р.Габделхакова

**Якынлаша төшү** Бераз якынлашу; тагын да якынлашу. *Якынлаша төшкәч, пароход тагы сызгыртты; сызгыртты да үзе, дулкыннар эченнән шаулатып, салны бер як ярга таба кысып үтеп китте.* Г.Ибраһимов. *Бераз якынлаша төшкәч, шул соры кибәннең бирге ягыннан, ыргытып бәргән шикелле иттереп, ат аяклары атылып-атылып чыга башлады.* Г.Бәширов

**Якынлашып алу** Тиз арада якынлашу; беразга якынлашу. *Солдаттан кайтып бер атна үтүгә, [Вахит] күрше авылның учителе белән якынлашып алды.* М.Гафури

**Якынлашып бетү** Бик нык якынлашу. -- *пароход, күп юл үтеп хәлдән тайган дәү бер җанвар кебек авыр мышный-мышный, ара-тирә ян-якка су парлары бөркеп, пристаньга якынлашып бетеп бара иде.* Ф.Сафин

**Якынлашып җитү** Тәмам якынлашу. *Якынлашып җитәргә өлгермисең: «Үсеп буламы, кем, энекәш?» – дип башлап сәлам бирә.* Р.Мөхәммәдиев. *Клубка якынлашып җиткәнче, бер-икесе шунда ук Казан кызлары белән танышып та өлгерде.* Ф.Яхин

**Якынлашып калу** Якынлашырга өлгерү; якынлашкан хәлгә килү. *Икенче танк Хәйретдин белән Мортазага бөтенләй якынлашып калган иде.* М.Яһудин

**Якынлашып килү** Әкренләп, азазлап якынлашу; якынлашуга таба бару. *Сәгать җиделәр якынлашып килә, мәктәпкә чыгып йөгерәсем бар.* А.Хәсәнов. *Әле утызга гына якынлашып килсә дә, илле яшьлек кешегә охшап, картаеп, ябыгып калган иде.* В.Нуруллин

**Якынлашып киту** Билгеле бер моменттан якынлашу. *Алар бит Альбина белән дә әнә шулай елга буенда кармак салып утырганда бик якынлашып киткәннәр иде.* Ш.Алпар

**Якынлашып кую** Берәр эш-хәлгә кадәр, алдан ук якынлашу; бик тиз якынлашу. *Бәхет байтак якынлашып куйган, Тик борылган капкам төбеннән.* И.Киньябулатов

**ЯКЫНЛЫК** *и.* 1) Нинди дә булса ике урын яки предмет арасы, ара озынлыгы. *Ара якынлыгы Сагынганда ерак, күрәмсең.* И.Юзеев // Үзеннән алда килгән сүзләрдән аңлашыла торган ара. *Иптәшләренә басмачыларны пулемёт уты өтәрлек якынлыкка китерергә, алдан өркетмәскә боерды.* Т.Әйди. *Биредә, түбәләре шифер белән ябылган читлекләрдә, күрше белән күршенең терсәкләре бәрелерлек якынлыкта хатын-кызлар урнашкан иде.* Н.Гыйматдинова

2) Якын булу хәле, урнашкан җире ерак булмау. *Искәрне чорнап торган татарлар, аткан тавышларның якынлыгына шикләнеп монда килеп җиткәндә, урман эче һәм елга буе мәетләр белән тулган иде инде...* Ф.Бәйрәмова

3) Вакыт аралыгы аз булу, кыска вакыт аралыгы. *Мин моның сәбәбен беләм: җиңүнең якынлыгын тоеп, тәгаен яшәүгә, язга омтыла иде халык.* Г.Гыйльманов

4) Охшашлык; нинди дә булса уртак як. *Туган иленнән читтә каңгырып яшәргә мәҗбүр ителгән ялгызак үз хәсрәте белән кыр казлары арасында якынлык таба, эчке охшашлык сиземли.* Т.Галиуллин. *Чыннан да, күзләрнең, кашларның каралыгындамы, йөз алсулыгындамы, әллә атлап йөрүдәме – ниндидер якынлык бар ич.* Х.Ширмән

5) Үз итү, хөрмәт итү, ярату, сөю, мәхәббәт хисе; җылы мөнәсәбәт. *Берберләренә карата берсе ана булып, икенчесе бала булып якынлык, туганлык хисләрен шулай озак сакласалар да, бергә булгач, аларның уртак ашлары пешмәде.* А.Хәсәнов. *Алар бер-берсен күңелләре белән аңласын, бу аңлашу чын рухи якынлыкка әверелсен өчен, бөтен көчен куяр Алтынчәч.* М.Маликова

6) Җенси мөнәсәбәт. *Зөлфия белән якынлыктан соң, ул үзендә мондый хис, ару, талу сизмәде.* Т.Галиуллин. *Әскәр Гөлсияне чын күңелдән яратса да, рәхәтләнеп күңел ачса да, якынлыкка батырчылык итми, аны күз карашы белән дә рәнҗетергә курка.* А.Нәҗми

**ЯКЫНЛЫК КЫЛУ** *ф.* Җенси мөнәсәбәткә керү. *Шуңа күрә дә без хатын-кыз затындагы кешеләр белән аралашмыйбыз, алар белән якынлык кылуны иң зур язык саныйбыз.* Н.Фәттах. *Җенси якынлык кылу – табигате белән нәфес билгесе түгел, ә нәсел үрчетү гамәле.* И.Әмирхан

**ЯКЫННАН** *рәв.* 1) Янәшәдән генә, ерактан түгел, ерак арадан түгел; шактый якын арадан. *Мәнә якыннан ишетелгән көчле тупның мәһабәт тавышы, юеш, караңгы урманның тынычлыгын бозып, урман буйлап шаулап китте.* К.Тинчурин. *Күп тапкырлар ишетеп, беркайчан да болай якыннан күрмәгән җитәкчеләре, аннан гайре Уфаның үзеннән килгән хәбәрче белән очрашуга төзүчеләр чиксез куанды.* А.Хәлим

2) Турыдан-туры үзе белән, арадашсыз; үз кеше буларак; үз итеп. *Соңрак, Казанга килеп, иҗат кешеләре арасында кайный башлагач, миңа Сара апа-*

*ның үзе белән дә якыннан танышырга туры килде.* И.Юзеев. *Гафифә әби белән якыннан аралашкан кешеләрне эзләп табарга һәм алардан шыпырт кына бу хакта сорашырга кирәк.* А.Гыймадиев

3) Яхшылап, ныклап; җентекләп, тәфсилләп. *Яшь аспирант монда илебезнең күренекле галимнәре белән йөзгә-йөз очраша, мавыгып, Финкельштейн, Уманский, Гуцов лекцияләрен тыңлый һәм атом-төш физикасы өлкәсендәге мәсьәләләр белән якыннан таныша.* Т.Әйди. *Тик, материал белән якыннан таныша башлагач, бу теманың кандидатлык диссертациясе өчен артык авыр булачагы ачыкланды.* Р.Юныс

**ЯКЫ́Н-ТИРӘ** *и.* **1.** Нинди дә булса бер урыннан ерак булмаган җир, тирә-як, тирә-юнь. *Өйләр бер-берсеннән ерак урнашкан иде, аннары, ярымкараңгы булганга, якын-тирәдә беркем күренми иде.* Н.Фәттах. *Бу төркемнең бурычы – яр буен һәм якын-тирәне тикшерү, разведкалау иде.* И.Хуҗин

**2.** *с. мәгъ.* Тирә-яктагы, якындагы; ерак булмаган. *Шуңа үзебезнең генә түгел, якын-тирә авыл кешеләре дә җәфалап бетерә иде аны, тегене тек тә моны теге бир, дип.* Ш.Җиһангирова

**ЯКЫНТЫН** *рәв. диал. к.* **якыннан**. *Гомумән, батальоннарга килгәч тә иң элек немец командиры белән якынтын аралашу аның төп кагыйдәсенә әверелде.* Ш.Маннур. *Хәер, югарыда әйткәнебезчә, кешеләр үзләре дә бик тату һәм берсе турында икенчесе якынтын кайгыртып яшиләр бу тирәдә.* Ф.Хөсни

**ЯКЫ́НЧА** *рәв.* **1.** 1) Үлчәү, сан, исәп-хисап белдерә торган сүзләр белән килеп, шулар тирәсендә, шул санга якын, шул чамада булуны белдерә; чама белән. *Хәзергесен исәпләп карыйк: өч мең тәңкәгә якынча өч йөз утыз өч ипи тия икән.* А.Хәмзин. *Фонд эшли башлаган көннән алып бүгенгә кадәр 340 миллион сумнан артык акча кергән: юридик затлардан 332 миллион сум тирәсе, физик затлардан якынча 9 миллион сум.* Н.Шәйдуллина

2) Азмы-күпме дөреслеккә якын итеп, җентекләп тормыйча. *Ә бүлек начальнигы Хәкимҗан абый, үзе конкрет белмәгәч, якынча гына сөйләп утыра.* М.Вәлиев. *Без инде эштән кайтып баручы бер төркем халыкка хәлне якынча аңлатып өлгергән идек, машинаны алар туктаттылар.* М.Әхмәтшина

**2.** *с. мәгъ.* 1) Төп-төгәл булмаган, гомуми. *Аларның гомуми күләме якынча исәп белән 750 бит тәшкил итә.* Л.Җамалетдинов. *Сезнең белән киңәшергә дип, якынча план да төзеп алып килгән идем.* М.Маликова

2) Азмы-күпме чынбарлыкка, дөреслеккә якын булган. *Үземне куандырганы: табындаш каләмдәшләрем белән хезмәт, иҗатымны белә-ишетә алган кадәренчә, иң мөһиме – якынча бәһа бирә алулар.* Г.Хөсәенов. *1941 елның ахырына совет әсирләренең гомуми саны якынча исәп белән өч миллион ярымга җитә.* Р.Мостафин

**ЯКЫ́НЧАЛЫК** *и.* Якынча булу; чама, якынча исәп; чама мәгънәсе. *Һичшиксез, мондый якынчалык тигезләмәләр системасын шактый гадиләштерәчәк.* Фән һәм тел. *Ул үзе бәйләнгән санның алдында килеп, аның мәгънәсенә якынчалык төсмерен өсти: «Мин бер егерме ел эшләдем тракторда (сөйл.)».* Татар грамматикасы

**Я́К-ЯККА** *рәв.* 1) Билгеле бер ноктадан төрле якка, тирә-якка. *– Юлбасар! – диешкә, чыпчык-песнәкләр як-якка борчак булып сибелештеләр.* А.Хәсәнов. *Солдатлар чылбыр булып як-якка сибелеп йөгерәләр.* Р.Вәлиев

2) Уртадан ике якка; ике якка таба. *Боргаланды-сыргаланды, терсәкләрен як-якка җәеп җибәрде, китапларын партаның әле бер җиренә, әле икенче җиренә күчерде.* Ф.Яруллин. *Яңа этапның килеп җиткәнлеген белдереп, сирена улап куйды, тимер капкалар, ыңгырашып, як-якка ачыла башлады.* И.Сираҗи

3) Әле бер якка, әле икенче якка. *Алда, наратлар арасында, бөтен юлны каплап, як-якка чайкала-чайкала килгән автомашина күренде.* Н.Фәттах. *Хатын, автоматны як-якка бора-бора, подвалдан чыкты.* Ф.Баттал

4) Төрле урыннардан бер үк вакытта төрле якларга. *Тик инде хәзер ул гөрселдәүләр баягы кебек үк шыксыз түгелләр, ничектер хәлсезләнебрәк, як-якка таралган сыман булып ишетелделәр.* М.Хәсәнов. *Коңгырт чәчләре тузгып як-якка таралган, кашлары, очарга җыенган кош канаты сыман, өскә талпынган, күзләре – чиксез моң һәм дәрт тулы күзләре – кешеләргә түгел, ә эчкә, үзенең эчке илаһи дөньясына төбәлгән кебек.* Р.Вәлиев

5) Төрле җиргә, төрле кешеләргә, тегендә-монда, тегесенә-монысына. *Китте як-якка сүз ташлау, китте гайбәт.* М.Хәсәнов

**Я́К-ЯКТА** *рәв.* 1) Билгеле бер ноктадан төрле якта. *Ил чигенә сакка китәбез, алда дошман, як-якта дошман, артта да дошман калмасын инде.* А.Гыйләҗев

2) Уртадан ике якта; кырыйларда; сул һәм уң якларда. *Як-якта берәр тәрәзә елмаеп тора, дарулар тезелгән пыяла шкаф, кечкенә өстәл һәм берничә урындык кына бүлмәне бизи.* Т.Галиуллин. *Директор кабинетының тәрәзәләре зурлар, биекләр, як-якта урындыклар, өстәлләр елык-елык ялтырап тора, чип-чиста.* Д.Каюмова

3) Ике якта да; әле бер, әле икенче якта. *Як-якта маякка кадап куелган чыбыклар күренгәли, әмма ул атның юл катысын тоюына, адашмавына күбрәк исәп итте.* Т.Әйди

4) Тирә-якта. *Елга уртасы, як-якта иркенлек, бушап калган кырлар, болыннар.* Ш.Галиев. *Буран һаман котыра, алда ак пәрдә, як-якта – күзне томалый торган шундый ук аклык.* Н.Әхмәдиев

**ЯЛ** I *и.* 1) Билгеле бер эш, шөгыльдән хәл алу, көч җыю өчен, вакытлыча туктап тору хәле; кыска тәнәфес, буш вакыт. *Дәресләрдән бушаган балалар көндезге аштан соң бүлмәләргә көндезге ялга таралды.* С.Сабиров. *Басуда төшке ялга туктагач, Габделхәйнең иптәш малайлары да рәхәтләнеп шаяралар аның белән.* Г.Галиев

2) Хезмәт, уку һ.б.ш.дан азат ителгән билгеле көн, атна, ай һ.б. дәвам иткән вакыт аралыгы; каникул; отпуск. *Ленизага, мөгаен, академик ял алырга туры килер.* М.Маликова. *Җәйге ялларында әнисе аны берәр атнага шәһәргә кунакка алып килә.* Ф.Җамалетдинова. *Икебезнең дә кесәдә чираттагы ял алдыннан алган хезмәт хакы бар иде.* С.Арсланова

3) Рәсми календарьда билгеләнгән, хезмәт, уку һ.б.ш. каралмаган көн (шимбә, якшәмбе, бәйрәм көне һ.б.ш. тур.). *Шулай, иртәгә ял, иртәгә бәйрәм!* Н.Фәттах. *– Ял көнне абыйларга кунакка барырбыз, – диде Әнвәр, саташкан кеше сыман.* М.Маликова

4) Физик яки рухи киеренкелектән бушану хәле; рәхәтлек, ләззәт, онытылу; җиңеллек, тынычлык. *Эче илаһидыр бу бинаның, юшкын баскан күңелләрне тазартырлык, тынгы белмәгән җаннарга ял бирерлек тылсымлы көч бардыр анда.* М.Маликова. *Әй, чукыр кош, чукыр кош, әйдә, чукы да чукы, сине күзәтеп торуы – үзе бер ял.* Н.Каштанов

5) Туфракның сыйфатын яхшырту өчен чәчми калдыру, парга калдыру алымы. *Мәлс ярсып китте: – Мин бит агроном кеше, Миңзаһит Усманович, – диде ул акланып, – җиргә ял кирәген беләм.* Ф.Садриев. *Тереклеккә ял кирәк булган кебек, безне тудырган Җиранабызга да ял кирәк.* Д.Салихов

6) *күч.* Туктап тору хәле, тик торыш; эшләмәү хәле (техника һ.б.ш. тур.). *Безгә алыштыргысыз хезмәт күрсәткән техникага да бераз ял кирәк бит.* А.Нургатина

**ЯЛ** II *и.* 1) Нинди дә булса эш башкару өчен, акча түләп яки билгеле бер шарт белән кеше алу күренеше. *Ял хакы*

2) Ялланып эшләгән өчен бирелә торган түләү; эш хакы. *«Без аңа барыйк, ул сине кунак итәр, хезмәт ялыңны түләр, әйдә, минем өстемә утыр, китик», – ди.* Әкият. *Гомерен саклап калу һәм тамак ялы өчен үз ишләрен сату эшенә алынгандыр, мөгаен.* Х.Камалов

**ЯЛ** III *и.* 1) Кайбер хайваннар муенындагы озын куе кыл. *Ханның башына әйтерсең лә тәпәч белән суктылар, ул ат ялы өстенә капланды.* М.Хәбибуллин. *Куе кара чәчләре арыслан ялыдай артка кайтарылып төшкән.* Р.Низамиев

2) *хуплм.* Артык озын чәч (ир-атта). *Шәһәргә китүгә ял үстергән*

**ЯЛА** *и.* Ялган гаеп, нахак гаепләү; ифтира. *Менә монда әле генә бер иптәш чыгып сөйләде: яла бит ул!* М.Мәһдиев. *Берни белмәгән гөнаһсыз Әмир кулын пычратмады, тик хәбәрченең якасыннан алып: «Әгәренки бу сүзләрең гайбәт, яла икән, үпкәләштән булмасын», – дип кенә әйтә алды.* Т.Галиуллин

**ЯЛАГАЙ** *и.* **1.** Кемгә дә булса ярарга тырышып икейөзлеләнүчән кеше. *Ялагай исә начальникка тугры, «безнең кеше» булып күренә.* Х.Камалов. *Һаман шул ялагай аяк астында урала икән.* Г.Тарханова

**2.** *с. мәгъ.* 1) Кемгәдер ярарга, ошарга тырышып икейөзлеләнә торган; яхшатлана торган. *– Син бигрәк ялагай кеше инде, – диде, ачулануын сиздереп.* Ф.Яхин. *Артта ялагай Сәлманның чыш-пыш килгән сүзләре яңгырап калды: – Бу да юха елан.* В.Имамов

2) Икейөзлеләнүне, ялагайлануны чагылдырган. *Алмыш хан, Ямгырчы бинең ялагай йөзен беренче тапкыр күргәндәй, кызарынган күзләре белән аңа сынап карады.* Н.Фәттах. *Чыраенда ялагай елмаю чагыла.* З.Хәким. *Туташларның ялагай карашын күрсә, Алинә, ачырганалып, коңгырт күзле ир-атның үзен хастаханәгә китерүен искә төшерә иде...* Х.Ширмән

**ЯЛАГАЙЛАНУ** *ф.* Кем алдындадыр икейөзлеләнү; яхшатланып ярарга тырышу; ошарга тырышып мактану, төче сүзләр әйтү, нидер эшләү. *Оясы алдында тыпыр-тыпыр биеп алып, хуҗасы каршында ялагайлана, кулын ялап ала, үз яныннан җибәрмәскә тырыша.* А.Вергазов. *Бар икән, нәрсә дип ялагайлана инде шуңа, җитмәсә, күпме күзләр карап торганда...* Г.Галиева

**Ялагайлана бару** Торган саен ныграк ялагайлану. *Исе дә китми кызның, ялагайлана гына бара.* Кызыл таң

**Ялагайлана башлау** Ялагайланырга тотыну. *Үзенең сизмәстән ялагайлана башлавыннан битләре кызышты, аркасына тир бәреп чыкты.* Ф.Садриев. *Ул Арысланга ялагайлана башлады: – Җанкисәгем, эшлә генә, зинһар.* Н.Гыйматдинова

**Ялагайлана бирү** Бернигә карамый ялагайлану; һаман да ялагайлану. *– Ярар, ялагайлана бир, нәтиҗәсе генә булмас, – диде абыйсы.* Идел

**Ялагайлана төшү** Бераз ялагайлану, тагын да ялагайлану. *Ялагайлана төшсәң, тыңлар да иде*

**Ялагайланып алу** Бер ара эчендә генә, аз гына ялагайлану. *Карчык саксызлык белән ычкындырылган сүзе өчен акланып маташты, аннары ялагайланып алды.* М.Хәсәнов

**Ялагайланып йөрү** Һәрвакыт, гел ялагайлану, озак вакыт дәвамында ялагайлану. *Алар үзләре үк хәзер минем алда ялагайланып йөри башладылар.* Н.Акмал. *Университетта, әллә кем булып, төрле җәмәгать эшләрендә катнашкан, укытучыларга ялагайланып йөргән бу адәм кызганыч түгел иде миңа.* Р.Сәгъди

**Ялагайланып карау** Сынау өчен ялагайлану. *«Ит-фәлән кирәк булса, әйт: үзем яздырып алып кайтып бирермен», – дип тә ялагайланып карады.* В.Нуруллин

**Ялагайланып тору** Гел, һәрвакыт ялагайлану; сөйләү моментында ялагайлану. *Икесе түзәрлек – сүз-йомыш сыя торган хатыннар, өченчесе, түше белән прилавкага ятып, кибетче Әсмабикәгә нидер сөйләп ялагайланып торучысы – Бибинурның игез сыңары Зөһрәбану иде.* А.Гыйләҗев. *Пенсионерлар алар куркып яки ялагайланып тормый: дөресен йөзеңә бәреп әйтә.* Шәһри Казан

**ЯЛАГАЙЛАНУЧАН** *с.* Һәрвакыт, гел ялагайлана торган; ялагайлану гадәте булган. *Ялагайланучан кеше*

**ЯЛАГАЙЛЫК** *и.* Ялагай булу сыйфаты. *Татар хатыннарына ялагайлык, ир теләген алдан тоеп тору җитешми шул, дигән күзәтүен күңеленә беркетеп куйды Салих.* Т.Нәбиуллин. *Намус белән эшлисең, көчеңне кызганмыйсың, ялагайлык, хәрәмләшү сиңа хас түгел, кешегә, халыкка мөмкин кадәр ярдәм итәсең.* З.Мурсиев

**ЯЛАМА** *с.* Ялау өчен файдаланыла торган; ялар өчен махсус ясалган. *Ялама тоз*

**ЯЛАМСАК** *с. сөйл.* Ашамсак; туя белмәгән, күп ашый торган; туймас. *– И кошчыгым, теге явыз яламсакның нәфсесе котырган... – ди ата, ачырганалып.* Н.Сәйяр

**ЯЛАМТЫК** *и. сөйл.* Сынык-санык, ашамлык калдыклары. *Яламтык эзләп йөрүчеләр күбәеп китте*

**ЯЛАН** I *и.* **1.** Үлән яки иген генә үсә торган, урмансыз, куаксыз һәм корылмалар булмаган җир. *Ялан күрер өчен, машинага утырып, әллә кая чабасы юк икән монда.* Ә.Еники. *Ләкин буш ялан, себергән буранның елап-чыңлап түй үткәрүенә кинәнеп, гамьсез генә ята бирде.* Д.Бүләков

**2.** *с. мәгъ.* 1) Бернәрсә дә үсмәгән; ачык; куаклар, корылмалар булмаган. *Әйлән-бәйлән уйный халык Ялан тау башларында...* Ә.Гадел. *Таш юлдан машина, дырык-дырык сикерткәләп, район үзәген чыгып киткәч, ул замандагы техникага хас булганча, мотор ике-өч тапкыр төчкерә дә сүнә, машина ялан кырда шып туктап кала.* А.Тимергалин

2) Берни белән дә капланмаган, бернәрсә киелмәгән, ачык; шәрә, ялангач. *Менә малай, ялан аягының очларына гына басып, ванна бүлмәсенә кереп китте, келәне шакылдатмаска тырышып, сак кына элде, суны да әз генә җибәреп агызды.* М.Маликова. *Шулчак аның ике ялан кулында берьюлы ике затлы хәнҗәр пәйда булды.* Р.Батулла

3) *к.* **ялангач** (*8 мәгъ.*). *Ялан кылыччлы, кара тәнле сакчыларның бер кылыч болгаулары алдында йөзәр, меңәр кеше җил белән өрелгән мамык шикелле чәчеләләр, бары аларның канга буялган җансыз гәүдәләре генә очлы кара ташларга асылынып калалар иде.* Гали Рәхим

◊ **Ялан кадәр** Зур, иркен (бүлмә, йорт һ.б. тур.). *Ишек-капкалары бикле ялан кадәр йортта япа-ялгыз кеше*

*көтеп утыру, гомумән, җиңел түгел инде ул, ә монда... таш та урыныннан кузгалыр.* Ә.Еники. *Аннан инде, ялан кадәр өйдә ялгыз башына урын таба алмагач, еш кына Мәхмүтләргә кереп утыра башлый.* Ф.Яруллин. **Ялан кебек** *к.* **ялан кадәр**. *Ялан кебек йортта ялгыз яши Бала бакмас «чибәр апалар».* Г.Мирһади. **Ялан хәтле** *к.* **ялан кадәр**. *Ялан хәтле өйдә кичләр һәм төннәр буе ялгыз уйланып ята торгач, акыл дигәнең буталып ук китә шикелле.* Ә.Баян. *Шушы ялан хәтле фатирда берүзең тордыңмы?* Ф.Яруллин. **Ялан чаклы** *к.* **ялан кадәр**. *Танышымның ялан чаклы йокы бүлмәсендә, ындыр табагы кадәр ятак янәшәсендә бер сәер сын – скульптура, борынгы мәҗүси бабаларыбыз телендә әйтсәк, серле «балбал» басып тора.* Г.Гыйльманов

**Я́ЛАН** II *рәв. диал.* Һаман, һәрвакыт, гел; һаман саен, даимән. – *Андый хәл ялан булып тормас инде, – диде Әлифә.* М.Маликова. *Андый зур җитәкчеләр безнең якларга ялан саен килеп тормый, гомумән, андый иптәшләрнең килүе – район өчен һәрвакыт зур вакыйга.* В.Нуруллин

**ЯЛА́НАЯК** *рәв.* **1.** Аяк киеме һәм оек кимәгән килеш; аяклар ачык килеш. *Әнием яланаяк кар өстенә чыгып баскан да бик бирелеп күкне күзәтә – мине эзли, ахрысы.* З.Хөснияр. *Чирәмдә яланаяк йөрсә, файдасы гына булыр, тәннәре ныгып китәр ие.* А.Әхмәтгалиева

**2.** *с. мәгъ.* Аяк киемсез, оексыз; яланаяклы. *Язларын, тауның көнгә каралган битеннән кар киткәч тә, күлмәкчән, яланаяк малайлар анда шайтан куа башлыйлар – мәтәлчек аталар, узыштан йөгерешәләр, көрәшкән булып әверенәләр.* Т.Мөбарәков. *Бәй, менә яланаяк бала эзләре...* Т.Гарипова

**ЯЛАНА́-ЯЛМАНА** *рәв.* 1) Яланып һәм ялманып. *Ялана-ялмана торгач, тамагы да туйды*

2) *күч.* Нидер өмет итеп, эзләнеп

**ЯЛА́НБАШ** *рәв.* **1.** Баш киемсез, башка кимәгән килеш. *Яланбаш, бишмәтсез басып торуымны абайлап алгач, әчем тагын ныграк бора башлады.* В.Нуруллин. *Шул арада ук карт тотарга өлгерә алмый кала, Мәликә яшен тизлеге белән ишекне ачып, яланаяк, яланбаш килеш тышка чыгып йөгерә.* Г.Галиев

**2.** *с. мәгъ.* Баш киемсез, башка кимәгән. *Тегеләрнең әрсезлеге Җәүдәткә ошамады, ул «сикермим» дип баш тарткан иде, шул арада бер хәл булып алды: урман юлыннан ак күлмәк кигән яланбаш бер кыз килеп чыкты.* А.Гыйләҗев

**ЯЛАНГАЧ** *с.* **1.** 1) Кием кимәгән; бөтенләй киемсез, шәрә. *Алай да кыз ак япманы ялангач тәненә каплап өлгерерлек көч тапты.* К.Кәримов. *Барыннан да бигрәк кунакның игътибарын җәлеп иткәне – ике тәрәзә арасында эленеп торган ялангач натурачы кыз сурәте.* К.Җәмит

2) Капланмаган, ачык; башлык, оек һ.б. кимәгән (гәүдәнең билгеле бер урыны, әгъзасы тур.). *Шулай, бу – Чулпан иде, өй халатыннан, ялангач аякларына өй чүәкләрен элгән килеш, октябрь азагы салкынын сизми, урамга атылып чыгып килә...* Х.Ширмән. *Аннары ул, аның артыннан мин дә, ялангач куллары белән идәнгә төшкән кызу күмер кисәкләрен алып, аларны кире мичкә ыргытучы әнигә карап тын калабыз.* М.Яһудин // Өске җылы киемсез. *Ялангач балалар кар атыша*

3) Үсемлек, агач-куаклар үсмәгән; үлән, үсемлек белән капланмаган, ачык урыннары күп булган (урын, ялан, кыр тур.). *Анда аларның кайберләре чыршы, нарат төбенә түшәлде, кайберләрен инде усал җил күреп алды һәм салкын кырга, ялангач яланга алып чыгып китте.* М.Мәһдиев. *Апакаем Миңгайшә, син ялангач җирләр өчен көенәсеңме?* Н.Гыйматдинова

4) Яфраксыз; яфрак ярмаган яки яфрагы коелган (агачлар тур.). *Шома, ялангач ботакларда бөре урынында саф энҗеләр җемелди.* Ш.Галиев. *Ялангач таллар арасында исә, йөрәкне мең телемгә телгәләп, ялгыз бер кош өзгәләнә.* А.Әхмәтгалиева

5) Берни дә ябылмаган, җәймәсез, ябусыз (өслек тур.). *Ялангач сәкеләргә менеп яткач та солдатлар әле бик озак сөйләшеп яттылар.* Г.Әпсәләмов. *Сумкаларын ялангач өстәлгә куеп, сүзсез генә кара-каршы утырыштылар.* Сөембикә

6) Бернәрсә белән дә җиһазландырылмаган, бизәлмәгән. *Шкаф өстендә бер глобус, ялангач стенада – ярымшарлар картасы.* М.Мәһдиев. *Майшикәрнең бөтен өен затлы мебель белән тутырдым, ә үземнең дүрт коттеджым да дала кебек шыр ялангач.* З.Мәхмүди

7) Кыныннан чыгарылган; кыны булмаган; һөҗүм итәргә әзер булган. *Кулындагы ялангач наганын һавада айкый-айкый сөйләде.* Л.Гыймадиева. *Миңлебайның уң кулы тураеп югары күтәрелде, һәм аның ялангач кылычы һавада чайкалгалап бара башлады.* Н.Яһудин

8) *сөйл.* Ярлы киенгән, хәерче кыяфәтле, киенерлек рәте булмаган. *Аны ерактан абайлаган авылдаш җиңгиләр, үзләре дә ач, балалары ялангач булса да, сөлгегә әз-мәз ризык төреп, урамга чыкмый калмыйлар иде.* Ф.Баттал // Ярлы, хәерче. *Кибетләр ялангач булса да, базар бай иде.* М.Кәбиров

9) *күч.* Коры, үтә гади. *Зур бер фикерне җиңел рәвештә әйтә алу – шагыйрьнең таланты булуын, әйтергә теләгән фикерен әтрафлы рәвештә белүен һәм ялангач формага түгел, бүгенге теләкләргә хезмәт итәргә теләвен күрсәтә.* Һ.Такташ

10) *күч.* Аңлатма бирелмәгән, коры, дәлилсез, расланмаган. *«Инкыйраз» ялангач фикерләрдән генә оешкан.* А.Тимергалин. *Ялангач фактлар. Ялангач цифрлар. Ялангач саннар*

11) *күч.* Бик сизгер; бик тиз яралап, үпкәләтеп була торган; яралы (җан, күңел тур.). *Ни хәл итим – җан ялангач, Шушы дөнья – остаханәм. Түбәсе юк...* Л.Зөлкарнәй. *Җанның ялангач чагы...* М.Кәбиров

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Киемсез рәвештә, шәрә килеш. *Ялангач атлаганын күз алдына китерүдән баягы күренеш калкып чыкты, һәм хатынының ачулы да, рәнҗүле дә тавышы яңгырады: – Мин башкача болай яши алмыйм.* М.Кәбиров // Гәүдәнең кайбер урыннары ачык килеш. *Башы ялангач калды.* Г.Ибраһимов. *Аннары ул яшел буяулы бакча рәшәткәсенә эленгән кулъюгычка лык тутырып шатырдаган салкын чишмә суы салды да, билгәчә ялангач калып, тирәюньгә чәчрәтә-чәчрәтә, күкрәген, беләкләрен шапылдатып юды.* А.Вергазов

2) Өске җылы киемсез, яланөс. *Тавыш зурга киткән, «янабыз, ахрысы» дип куркып, күрше-тирәләр ялангач килеш йөгерешеп чыкканнар.* Кызыл таң. *Урамга ялангач чыкмагыз, бик салкын*

3) Үсемлексез, агач-куаксыз булып, игенсез, буш килеш; берни дә үсми торган хәлдә. – *Үсми ул, басуны ялангач калдырасың, башбаштак! – дип, рәис пыр тузынса да, вәгъдәсен бозмады.* Н.Гыйматдинова. *Көзне шуннан беләбез – Саргая куак-агач, Кырлар кала ялангач.* Р.Корбан

4) Кыныннан чыгарып; кынсыз килеш (кылыч тур.). *Урам буйлап, берсе алдан, икенчесе Чулпаныңның артыннан, берсе кылычын ялангач тотып,*

*икенчесе алтатарын Чулпанының сыртына терәп, участокка алып киттеләр.* Р.Батулла

5) *күч.* Ачык, саклаусыз хәлдә, тиз яраланучан булып (җан, күңел тур.). *Күпләргә кәмит, яралы җаның ялангач калгач...* Р.Фәйзуллин. *Шул караш астында күңелем ялангач кала да, бер гөнаһсыз, садә хис-уйларым, ояла-ояла, яшеренер урын эзли кебек.* Р.Габделхакова

6) *күч.* Ачыктан-ачык итеп, турыдан-туры. *Әдәбиятның бурычын һәм максатларын, «әдәби образ» төшенчәсен минә шулай үтә ялангач итеп аңлату белән килешеп булмый.* Ф.Миңнуллин. *Ләкин әлеге әсәрләрдә геройлар табигый булмаган ситуациядә ялангач итеп биреләләр.* К.Гыйззәтов

**3. ялангачлар** *и. мәгъ.* Ярлы-ябага, фәкыйрь-фөкара, хәерче кеше. *Әдип фәкыйрьләрне, ятимнәрне, ялангачларны, авыруларны, мөшкел хәлдә калучыларны чын күңеле белән кызгана, үз укучыларын аларга теләктәшлек кылырга, ярдәм итәргә чакыра.* Х.Миңнегулов. *Көне-төне камыт киеп тарткан хокуксызлар – ачлар, ялангачлар – өметләнеп бәхет көттеләр.* Н.Фәттах

◊ **Ялангач калдыру** Талап, урлап яисә башка берәр юл, ысул белән хәерчелеккә төшерү; байлыгын юк итү; бөлдерү. *Уйнаш күңелле кыз-хатыннар сине теләгәнчә алдый, ялангач калдыра, хыянәт итә, аяк астындагы тузанга әвереләдерә ---.* Р.Зәйдулла. *Эшне озакка сузмыйча, «бу мине шыр ялангач калдырмагае» дип, Әбүбәкер икенче көнне үк өйдә булган бар акчаны Сбербанкка алып барып үз исеменә салып кайтты.* И.Хәйруллин. **Ялангач калу** Хәерчелеккә төшү, бөлү; акчасыз, байлыксыз калу. *Кайгысы зур булган шул, малай: карт хатынын, эчәргә дә бирми дип, аерган, яшьне алган, яшь хатын алу белән, ялангач калган.* Һ.Такташ. *Ач булырбыз, ялангач калырбыз, әмма азатлыкны яуларбыз.* К.Кәримов

**ЯЛАНГА́Ч БАЛЫК** *и. зоол.* Сөләйман балыклар семьялыгыннан янякларында гына булган вак тәңкәләре бөтенләй диярлек күренми торган ялангач гәүдәле эре балык; *русчасы:* **голец**. *Ялангач балыкның ите кызыл төстә*

**ЯЛАНГАЧЛАНДЫРУ** *ф.* 1) Ялангач хәлдә калдыру, шәрәләндерү. *Утырганда сиздерми генә тезләрен ялангачландырырга онытмады.* Ә.Гаффар. *Басу уртасында ялгыз карачкы Каратайның алагаем олы гәүдәсе, ялангач кырны тагын да ялангачландырып, берүзе басып торган көне.* Р.Батулла

2) Кыннан чыгару. *Алар, сафта баручыларга сүз катмакчы булып, әледән-әле тоткыннарга якынлашалар, әмма кылычларын ялангачландырып тоткан солдатлар, ачулы сүзләр белән җикеренеп, аларны читкә куа торалар иде.* М.Галәү

3) *күч.* Гадиләштерү, турыдан-туры, ачык итеп әйтеп бирү. *Хисам Камалов тойгыларны ялангачландырып бирми: нәфрәт булса да, мәхәббәт булса да шулай.* С.Маннапов. *Әсәрдә кеше тормышы һәм психологиясе турыдан-туры биологик һәм физиологик сыйфатлары белән ялангачландырып күрсәтелә.* З.Сәлахова

**Ялангачландыра бару** Торган саен ныграк ялангачландыру. *Авыр еллар халыкны ялангачландыра бара*

**Ялангачландыра башлау** Ялангачландырырга тотыну. *Көзнең салкын җилләре агачларны ялангачландыра башлады*

**Ялангачландыра төшү** Тагын да ныграк ялангачландыру. *Әсәрдә төрле группа талашлар, саннар белән группаларга бүленеп көрәшүләр, чуваш коммунистлары арасындагы группалар турындагы фәлсәфәләр мөндәриҗә бөтенлеге өчен бернәрсә дә өстәмәгәннәр, киресенчә, хикәяне бераз коргаксыта, анда агитация элементларын ялангачландыра төшкәннәр.* Г.Ибраһимов. *Һәм автор моны тагын да ялангачландыра төшеп: «Һәрхәлдә, ул Вилданга кирәк иде – һәм ул калды», – дип өсти.* Ф.Хөсни

**Ялангачландырып бетерү** Тәмам ялангачландыру. *Көчле җил агачны ялангачландырып бетерде*

**ЯЛАНГАЧЛАНУ** *ф.* 1) Киемсез калу; ялангач калу; гәүдә ачык калу; өлешчә киемсез калу. *Әле килен булып төшкәненә өч көн барлы-юклы гына, шул арада ялангачланып, өлкән җиңгәләр алдында тән күрсәтеп торырга кыюлыгы җитмәде, тик оек-чабатасын салды да ак аякларын суга тыкты, җиңнәрен сызганып, култбашынача суда рәхәтләндерде, бөркәнчеген ташлап, битен, муеннарын юды.* Г.Ибраһимов. *Туның салып бирмә. Алда салкын томан, Ялангачланма, их, Шәрә бүре сыман ---.* Б.Рәхимова

2) Яфраклары коелу; шәрә калу (агачлар, куаклар тур.). *Күп агачлар ялангачланды, кыш яшелләнә торган карагачлар гына үз төсенә керә башлады.* С.Шәрипов

3) Үләнсез, агачсыз, урмансыз һ.б. калу (табигать тур.). *Минә бервакыт агачларда яфраклар коелып беткән, табигать ялангачланып, шыксызланып калган.* Г.Гыйльманов

4) Берни дә капланмаган килеш, тулысынча күренеп, ачылып калу. *Югыйсә җир ярыла, тамырлар өзелә, ялангачлана, кибә.* Ә.Гаффар. *Кайдадыр Идел аръягында үле, черек балыкларның ак тәннәре сибелгән, мазуттан каралган сайлыклар ялангачланган, урманнар яна.* Сөембикә. *Яшь кенә хатынның аскы тешләре хәтта ялангачланып, тамырлары ук күренеп торган була.* Кызыл таң

5) Җиһазсыз, бизәлешсез калу. *Мәчтүрә апаның болай да мескен өе ялангачланып, боегып киткәндәй булды.* Җ.Рәхимов

6) *күч.* Тулысынча ачылу, ачык сизелү, беленү, аңлашылу. *Әйтерсең аның ялангачланган эчке сыйфатын карт белгеч шунда ук күреп алды.* А.Расих. *Билгеле инде, куркыныч каршында характер ялангачлана: кемнең кем икәнлеге, нәрсәнең нинди булуы хак төсендә, шулай әйтергә ярасa, натураль рәвешендә алга килеп баса.* Ә.Баян

7) *күч.* Ярлылану; хәерче, ярлы булып калу; бөлү; матди хәле начараю. *Халык ялангачланды. Авыллар ялангачлана*

**Ялангачлана бару** Торган саен ныграк ялангачлану. *Кара урманнарыбыз азая, урманнарны алан алыштыра, аланнар ялангачлана бара.* Г.Хөсәенов. *Инсаф белән Ансаф, тәрәзә төбенә утырып, өй эченең бушый, ялангачлана барганлыгын шым гына күзәттеләр.* Т.Гарипова

**Ялангачлана башлау** Ялангачлануы беленү, күренү. *Көзгә каршы саргая, ялангачлана башлаган биек агачлар арасыннан озын бер сукмак бар.* Г.Ибраһимов

**Ялангачлана төшү** Бераз ялангачлану; тагын да ялангачлану. *Агачлар ялангачлана төште*

**Ялангачланып бетү** Тәмам ялангачлану; бөтенләй ялангачлану. *Кырлар ялангачланып бетте*

**Ялангачланып калу** Билгеле бер вакыттан яки тәэсирдән соң ялангачлану. *Шомырт ботаклары ялангачланып калды; тирәк белән каен агачлары үлем күләгәсе төсле булып басып торалар иде.* М.Галәү. *Ялангачланып калган борчак басуына җиткәндә, кичке эңгер төшкән иде инде.* Д.Бүләков

**Ялангачланып кую** Алдан ук ялангачлану; тиз арада ялангачлану. *Беренче кар төшкәнче, урман ялангачланып куйган иде инде.* Кызыл таң

**ЯЛАНГАЧЛА́У** *ф. к.* **ялангачландыру**. *Падишаһ, ачуланып, кылычын ялангачлап, сандыктагы егетне сандыгы-ние белән уртага өзәем, дигәндә, хатын әйтте: «И падишаһ, син диванамы булдың, гакылың кая китте?»* К.Насыйри. *Менә көз барча кырларны вә урманны ялангачлый. Менә, ак тун киеп, инде күңелсез кыш килә башлый.* Г.Тукай

**Ялангачлап кую** Алдан ук ялангачлау, ялангачланган хәлгә китерү. *Кылычларны ялангачлап куярга кирәк, дигән уй йөгереп үтте мизгел эчендә.* Кызыл таң

**Ялангачлап тору** Алдан ук ялангачлау. *Кылычларны ялангачлап тору*

**Ялангачлый бару** Торган саен ныграк ялангачлау

**Ялангачлый башлау** Ялангачларга керешү

**Ялангачлый төшү** Бераз ялангачлау, тагын да ялангачлау. *Җил-давыл агачларны ялангачлый төште*

**ЯЛАНГАЧЛЫК** *и.* 1) Ялангач (*1, 2, 4–8 мәгъ.*) булу сыйфаты. *Лос-Анджелес гостиницасына кергән чакта игътибар иттек: уң тарафта бик зур полотнода ярымъялангач хатын-кыз кырын ятып тора, сул тарафта – шундый бер хатын-кыз кап-кара костюмлы ир белән янәшә ята, күрәсең, хатын-кызның ялангачлыгы кара фонда ныграк күзгә ташлана.* М.Вәлиев. *Килер бер көн: каен бушап, ялангач булып калыр, менә шунда ул, үзенең шыксыз ялангачлыгыннан оялгандай, аска таба сузылып төшкән нечкә сыгылмалы ботакларын әле кәүсәсенә кысар, әле аларны холыксыз җил иркенә куеп, уңга-сулга селтәр ---.* Х.Ширмән

2) *күч.* Ярлылык, хәерчелек, бөлгенлек. *Ачлык белән ялангачлык аның канына сеңеп калгандыр, дип уйлыйм үзем.* З.Зәйнуллин. *Ялангачлык ялмап тотар – чыдарсыңмы, Яман ачлык белән сынар – сынмассыңмы?* М.Мирза

**ЯЛА́Н-ЙОЛАН** *рәв.* Әле тегендә, әле монда; бер урында туктамыйча, бер нәрсәдән икенчесенә йөгереп; алак-йолак; алан-йолан. *Ялан-йолан каранакарана, малай учындагы җимне чукый да башлады.* Г.Гыйльманов

**ЯЛА́НКУЛ** *рәв.* 1) Бияләйсез, перчаткасыз; ялангач кул белән; кулга берни кимичә. *Җәй көне ярыйдыр, ә менә кышкы салкыннарда ялankул йөри күрмәсен.* Р.Низамиев. *Кем ялankул йөрде икән, исеңдә юкмы?* Аманулла

2) *күч.* Коралсыз. *Сыртакның ялankул тереләй бүре алуы, бүресе белән тере бәрән дә алып кайтуы турында тирә-юньдә ишетмәгән авыл калмады.* Р.Батулла. *Ялankул бүре аулаган Солтанбәк ирләрен эт дәрәҗәсенә төшерергә берәүнең дә хакы юк!* Н.Гыйматдинова

**ЯЛА́Н-КЫР** *җый. и.* Яланнар һәм кырлар. *Бөтен ялан-кырларга без чәчеп, без урып, печәнне дә без, татарлар, чабып яшәдек.* З.Зәйнуллин. *Гәүдәгә таза, киң җилкәле, әтисе белән гел ялан-кырда йөргән, җәнлек аулаган, агач кискән егеттә аюныкы кебек көчгайрәт тә булмагач.* Г.Якупова

**ЯЛАНЛЫ** *с.* Ялан, тигез ачыклык рәвешендәге. *Өченче көндә яланлы җирләргә килеп чыктык.* М.Гафури. *Ходай әллә ялваруын ишеттеме, ябык машинада ярты көн чамасы юл үтеп, ниндидер хутор кебек яланлы җиргә килеп төштеләр...* С.Лашманчы

**ЯЛАНЛЫК** *и.* Ачык тигез урын, ялан, аклан; агачлар, корылмалар булмаган ачык, иркен җир. *Ул чокырлар аша сикерде, тауларга менде, яланлыкка чыкты, куе-куе агачлар арасыннан үтте.* Г.Кутуй

**ЯЛА́НӨС** *рәв.* 1) Өске кием кимичә; киемсез. *Асаф яланбаш, яланөс абзар артына таба караңгылыкка кереп югалды.* М.Мәһдиев // Бөтенләй киемсез; ялангач килеш. *Яланөс, яланаяк, анадан тума гөнаһсыз бала.* Ш.Галиев. *Билгә кадәр яланөс, кулда юка резин перчаткалар.* Р.Фәизов

2) Җылы киемсез; җиңелчә киенеп. *Мин сиңа әйтә килдем, яланөс чыгып йөрмә, калынрак киен, грипп эләктерәсең, дидем.* Ф.Садриев

**ЯЛАНТА́У** *и.* Ялангач, шәрә таулык. *Ихтимал, элек куе урман белән капланган булгандыр, хәзер исә ул ялантаудан гыйбарәт.* А.Тимергалин

**ЯЛА́НТӘН** *рәв.* Ялангач хәлдә, шәрә килеш. *Хатын, авызына килгән беренче сүз – бисмилласын әйтеп, ялантән мунчадан чыгып йөгергән.* М.Мәһдиев

**ЯЛА́НТӘПИ** *рәв. к.* **яланаяк**. *Иртәнге салкын чыктан ялантәпи атлаган Илсөянең, бәрәңге араларында ватылмый калган кәсләргә баса-баса, аягы авыртып бетте.* М.Әхмәтшина. *Ялантәпи йөрисе иде бит әнә шул чишмә янындагы йомшак, назлы чирәмнәргә!* М.Вәли-Барҗылы

**ЯЛАНУ** *ф. кайт. юн.* 1) *к.* **ялау** I (*1 мәгъ.*). *– Сыегыз өчен рәхмәт, – диде ул, ялана-ялана.* Р.Вәлиев. *Калач китергәннәр каладан. Шул чакларны искә алган саен, Һаман әле тәмләп яланам.* И.Киньябулатов // Үз-үзен ялау (хайваннар тур.). *Шелтәне аңлагандай, песикәй ялана-ялана чистарына.* Ш.Галиев. *Сиражи тасвирлаган – тамагы тук, бернинди проблемасыз, дөньясы түгәрәк, кәефле, диванда яланып яткан ата мәче күз алдына килә...* Безнең гәҗит

2) *төш. юн. к.* **ялау** (*1 мәгъ.*). *Берничә минутта чүлмәк бушады, кашыклар, савытлар яланды.* Г.Ибраһимов. *Бармаклар Яланды. Торт бетте, Калмады.* Л.Шәех

3) Ныклап ашамау, аз-маз гына капкалау; чемченеп кенә утыру. *Берәү ашап туя, берәү яланып кала.* Әйтем. *Акмаса да, тама иде, корсагың тулганчы ашамасаң да, яланырга табылып тора иде.* Р.Миңнуллин

4) Тел белән тидергәләп, сыпырып җыя-җыя ашау, эчү (хайваннар тур.). *Сарыклар яланып йөри*

5) *күч.* Ялагайлану; ярарга тырышу; ялагайланып, нәрсәдер өмет итү, көтү; ялману. *Чын язучы белми, белсә – аңламый: хакимият тирәсендә яланып йөрүче теге ялагайларның мактау сүзләрен һәм дәүләт бүләкләрен үзара оештырып, хәрәмләшеп алуларын аңламый ул.* М.Юныс. *«Ул да хуҗалар тирәсендә койрык болгап, яланып яшәүче бер шәхес булган лабаса!» – дигән уйга килә.* З.Шаһиморатов

6) *күч.* Кая да булса бик еш йөрү, шул тирәдә еш булу, чуалу. *Һаман шулар йорты янында яланасың*

**Ялана башлау** Яланырга тотыну. *Эт ялана башлады*

**Ялана бирү** Бернигә карамый ялану; һаман да ялану. *Песи һаман ялана бирде, сыйпаганга исе дә китмәде.* Ялкын

**Ялана төшү** Бераз ялану, тагын да күбрәк ялану. *– Бигрәк тәмле, – диде малай, ялана төшеп.* М.Вәлиев

**Яланып алу** Кыска гына вакыт, аз гына ялану. *Балаларның кулларындагы туңдырманы күргәч, малай яланып алды.* Р.Вәлиева

**Яланып бетү** Бик нык ялану. *Янналары кимерелеп, төпләре яланып беткән улаклар абзар артына ук чыгарып өелгән.* Ә.Гаффар. *Ул тавышсыз-тынсыз гына мәгарә түренә узды, яланып бетмәгән болан сөяге табып, бик канәгать кыяфәт белән җайлап утырды да*

*аны шатыр-шотыр кимерә башлады*. Р.Вәлиев

**Яланып йөрү** Шактый вакыт ялану. *Гел шулай яланып йөри ул*

**Яланып кую** Көтмәгәндә, кинәт кенә ялану. *Әиреннән җиләк сулары әллә кайчаннан ага башлаганнар иде инде минә, яланып та куйгалыйм.* Ф.Яхин. *Кыз балны кабып яланып куя.* Р.Гаязетдин

**Яланып тору** Әледән-әле, еш ялану; хәзер ялану. *Рәшәткә буенда сарыклар яланып тора*

**ЯЛАНЫ́П-ЯЛМАНЫП** *рәв. к.* **ялана-ялмана**

**ЯЛА́Н-ЯЛАН** *рәв. диал.* 1) Һаман, һәрвакыт, һаман-һаман. *Абый җаным, ялан-ялан майлы ботка булмый, егылмас борын елама әле.* Г.Әпсәләмов. *Ялан-ялан кабатлап тора алмам.* Т.Галиуллин

2) Бик еш. – *Бер чыгып киткәч чит якларга, ялан-ялан кайтып йөреп булмый шул, – дип сузды Мәҗит бераздан.* Н.Акмал. *Ялан-ялан Казанга килеп йөреп булмый.* Ф.Яруллин

**ЯЛА́Н-ЯПА** *с. сөйл. к.* **ялан-япан 2**. *Ялан-япа далада ун мең, йөз мең атлар, кешеләр белән, көтүләр белән мин нишләрмен?* Н.Фәттах

**ЯЛА́Н-ЯПАН** *и.* **1.** Торак җирдән, кешеләрдән ерак; сыеныр урын булмаган урын. *Бер мәлне агалары ялан-япанда Заятүләкнең аргамагын чатанлатып, йөгәнен алып, үзен куып җибәрәләр.* Р.Әхмәтҗанов

**2.** *с. мәгъ.* Агач-куак үсмәгән. *Бер заманда патша, хатыны белән икәү, яхшы атлар, яхшы арбалар җигеп, ялан-япан сахрага чыктылар*. Әкият. *Ялан-япан җирдә исә имән-нарат, тирә-юньгә хуҗа булгандай, таралып-җәелеп, баһадирдай мәһабәт, гайрәтле булып үсә.* Ф.Хатыйпов

**ЯЛАТТЫРУ** *ф. йөкл. юн. к.* **ялату**. *Кибеттән «Эскимо» алып чыгып, үзләре ашыйсы урында маэмайдан ялаттыралар.* А.Хәсәнов. *Аннан соң табаныңны куштаннарга ялаттырма!* Р.Батулла. *Чөнки инде юган, чистарткан урыннарны кабул итмичә, берничә тапкыр «ялаттырып» теңкәгә тиде.* Безнең гәҗит

**ЯЛАТУ** 1) *ф. йөкл. юн. к.* **ялау** I. *Ләйсәрияне кочаклап торганының, көлә-көлә, аяк астында бөтерелеп йөргән эт баласын күтәреп алуы һәм шуннан үзенең битен ялатуын аңлый да алмады Нурҗи, аңлата да алмас.* Ж.Юныс

2) Күзгә чүп кергәндә, башка кешедән тел белән шуны ялап алуын сорау. – *Өеңә кайткач, [чүпне] әбиеңнән ялатырсың, – дип кырт кисте Зиләйлә. Һәм, шкафтан нәни генә шешә, пипетка алып, салкынча бармаклары белән егетнең күз кабакларын киереп, дару тамызды.* М.Маликова

3) Әз генә сөртү, тидерү, йөгертү. *Ай сызлап та күрсәтте соң, ислемай ялаткан энә белән көчкә тартып чыгардылар үзен.* Р.Низамиев. *Армиядәге өлкән улы алып кайткан алтын ялатып эшләнгән авторучкасының өстәлендә юклыгына күз йомып, рус теле дәресен дәвам иткән дә булыр иде...* Кызыл таң

4) *күч.* Камылны, үлән сабакларын бик кыска калдыру өчен, чалгы, урак, ургычны җир өстенә бик якын йөртү. – *Камыл өстенә салынган башакларны ялатып алып барырга кирәк. Бер бөртек тә әрәм булмасын, – дип орыша.* М.Гәрәев. *«Безне мыскыл итеп утырмасыннар, безнең нәселдә печәнне ялатып чабалар», – диде ул.* Кызыл таң

5) *күч.* Кат-кат сөрттерү, юдыру, чистарттыру. *Зур кунаклар килер алдыннан бөтен җирне ялатырга тотыналар*

**Ялата башлау** Ялатырга тотыну. *Сыерга тоз ялата башладык*

**Ялата бирү** Бернигә карамый ялату; һаман да ялату. *Исе дә китми, эттән битен ялата бирә.* Идел

**Ялата төшү** Бераз ялату: тагын да күбрәк ялату. *Тоз ялата төшәргә кирәк*

**Ялатып йөрү** Озак вакыт дәвамында ялату. *Исламның шулай стакан төбе ялатып йөрүенә аның җаны үртәлде.* Н.Фәттах

**Ялатып кую** Алдан ук ялату; тиз генә ялату. *Әз генә ислемай ялатып куйдык*

**Ялатып карау** Ялатырга тырышу; сынау өчен ялату. *Һи, ул бодай кырындагы җиլләрдән тәнеңне ялатып кара әле – сахраларның киңлегеннән, чисталыгыннан, сафлыгыннан башлар әйләнмиме соң!* Ж.Юныс. – *Нәрсә, әллә син дә [башны] сыерга ялатып карарга уйлыйсыңмы? – дип, шаркылдап көлеп җибәрдем.* Ә.Дусайлы

**Ялатып тору** Гел яки әледән-әле ялату; сөйләү моментында ялату. *Хәлим бозаулардан учын ялатып торган арада, каяндыр йөнтәс эт килеп чыкты.* Г.Гыйльманов

**ЯЛА́У** I *ф.* 1) Нәрсәне дә булса тел белән сыпыру. *Койрыгын ялый икән, димәк, мәче юына.* Г.Гыйльманов. *Иреннәрен ялый-ялый балык тазарткан киленгә бианасы бер генә карады һәм уйлаганын кычкырып әйтте: «Малай булыр микәнни?»* Д.Булатова

2) Тел белән тидергәләп, сыпырып җыя-җыя ашау, эчү (хайваннар тур.). *Мич каршында ала песи баласы тәлинкәдән сөт ялый.* Г.Әпсәләмов. *Сыерлар тоз ялаганда, бозаулар боз ялый.* Д.Салихов

3) *күч.* Бик тиз генә кыздырып, көйдереп, яндырып алу (ут, ялкын, кояш һ.б.ш. тур.). *Ялкын ялый кыекны! Ут нәкъ безнең физика бүлмәсендә, Төтен...* М.Җәлил

4) Эретеп, киптереп һ.б. юкка чыгару. *Хәзер әнә язгы сулар әз-мәз җыелып ала да, кояш ялый башлагач, бетә дә китә.* А.Гыйләҗев

5) *күч.* Нәрсәнең дә булса вакыт-вакыт берәр өлеккә тиеп китүе. *Дулкыннар бер-бер артлы бетон ярны ялый.* М.Маликова. *Тәрәзәмне кышкы яңгыр ялый, Бәлки шулдыр җанны сыкрата.* М.Сәгъдиев. *Аерылабыз. Эзләрне җил ялый.* Р.Зәйдулла

◊ **Ялап куйган кебек** Шома яки бик чиста. *Тәмледер, ахырда барысының да тәлинкәләре ялап куйган кебек чип-чиста калды*. Алабуга нуры

**Ялап алу** Берара, аз гына ялау. *Оясы алдында тыпыр-тыпыр биеп алып, хуҗасы алдында ялагайлана, кулын ялап ала, үз яныннан җибәрмәскә тырыша.* А.Хәсәнов. *Аклы-каралы йомгак шикелле тәгәрәп аяк очыма килде, шыңшый-шыңшый, туфли башын ялап алды.* А.Тимергалин

**Ялап бетерү** Тулысынча, барысын да ялау; ялауны тәмамлау. *Авылга җитәрәк, соңгы үрне күтәрелгәч, караңгылыкны кызыл телләре белән ялап бетерергә теләгәндәй, үргә үрләп ялкынланган учак күренде.* Т.Гарипова. *Нәүбәһәр үзе дә, ашказаны суыруга түзә алмыйча, кайтып җиткәнче, онның яртысын ялап бетерә торган иде.* Ф.Җамалетдинова

**Ялап йөрү** Гел ялау, озак вакыт дәвамында ялау. *Берме, икеме атнадан соң, без әле һаман да бал тәме килгән иреннәребезне генә ялап йөри башладык.* Р.Кәрами. *Сез ашаганнан калган сөякне өч көн буе ялап йөрер идем.* Л.Лерон

**Ялап калу** Яларга өлгерү; моментыннан файдаланып ялау. *Ялагайлар, койрык болгап, Кулны ялап калыгыз.* И.Юзеев

**Ялап кую** Көтмәгәндә, кинәт яки тиз арада, озакка сузмыйча ялау. *Ашап, тәлинкәсен ялап куйганнан соң, Газинур аны буш торган оясы алдына җи-*

*тәкләде.* А.Хәсәнов. *Ашап бетергәч, кашыкның эчен дә, тышын да ялап куярга кирәк.* Р.Батулла

**Ялап тору** Гел, даими ялау; сөйләү моментында ялау; билгеле вакыт дәвамында ялау. *Бармакларына агып төшкән соңгы мороженыен ялап торган малай моны искә дә алмады.* Р.Мөхәммәдиев. *Куыклы лампа яктысында калын тавыш белән мөгри-мөгри яңа туган бозавын ялап торган сыерны күргәч, күңеленә җылы керде.* М.Кәбиров

**Ялый бару** Һәрберсен, булган берсен бер-бер артлы ялау. *Этккә сөяк ташлагандай кар коела, Таш урамнар ялый бара һәр бөртеген...* Л.Гыйбадуллина

**Ялый башлау** Яларга тотыну. *Егет, кычытканга чагылган баладай, уч төбен ялый башлады.* К.Кәримов. *Беләсеңме, Ялкынны саварга утыруым була, башын бора да битләремне, чәчләремне ялый башлый.* Ф.Җамалетдинова

**Ялый бирү** Бернигә карамый ялавын дәвам итү. *Камыр түгелә, бозау ялый бирә.* Әкият. *Аларга игътибар итмәстән, ул һаман комсызланып ялый бирде.* Ф.Яхин

**Ялый тору** Башка бер эш-гамәлгә кадәр яки шул эш башкарылган вакытта ялау. *Борһан ага, сварщикларны да ияртеп, безнең янга килеп җиткәндә, без, телләребезне бер карыш чыгара-чыгара иреннәребезне ялап, бик тәмләп буран суы эчеп утыра идек – тел очына буран учлап-учлап кар сибә тора, без ялый торабыз.* Р.Төхфәтуллин. *Әнисә уйлап та тормады, туңдырмасын ялый торгач, бер туктаган арада: – Беләм, – дип әйтеп куйды.* Д.Бүләков

**ЯЛА́У** II *и. иск.* 1) Байрак; әләм. *Шуңа күрә татар телендә ялау дип байрак-әләмне дә, тун төймәсе өчен ясалган элмәкне дә атыйлар.* Р.Әхмәтьянов. *Әмма Япанча поскын гаскәр барын белде, чөнки Казан каласының иң биек манарасы Илекмән түбәсеннән аңа ялау болгыйлар.* Р.Батулла

2) Аерма билгесе буларак, гаскәриләр баш киеменә куела торган кечкенә әләм. *Шлем ялавы*

3) *диал.* Төймә элмәге. *Тунның ялавы өзелгән*

**ЯЛАЧЫ** *и.* **1.** Яла ягучы кеше; ифтирачы. *Котылалмый һаман гөнаһыннан: «Ялачы» дип яман дан чыккан.* И.Юзеев. *Кызыл комач ягы: «Син – ялачы!» – дип кычкыра.* Р.Батулла

**2.** *с. мәгъ.* Яла яга торган; яла ягучы. *Авантюрист, ялачы Курамшин кайда?* Г.Ахунов. *Ялачы хатын кирәкме сиңа?* А.Гыйләҗев

**ЯЛАШУ** *ф. урт. юн.* 1) *к.* **ялау** I (*1 мәгъ.*). *Соңгы сүз шул гына: үҗәт булыйк, усал булыйк, эткәшеп, тешләшеп, соңыннан ялашып, дуслашып, эт елында чын этләрчә яшик, җәмәгать.* Ф.Дәүләтбаев

2) *гади с.* Үбешү. *Без кешечә торабыз. Ялашкан чаклар да, талашкан чаклар да булыр.* Р.Батулла. *«Ир-хатын талашыр, кич җиткәнче ялашыр» дигән гыйбарә шуны аңлата бит инде.* Ю.Сафиуллин

**Ялашып тору** Озак ялашу; хәзерге моментта ялашу. *Сарык бәрәннәре берберсен ялашып торалар*

**ЯЛБЫР** *с.* 1) Озын һәм куе (йон, ябага, чәч тур.). *Бик искергән, кыйшайган табанлы ботинкалар, билгесез төстәге чалбар, җиң очлары сүсәреп, итәкләре каешланып беткән фуфайка, күптән кырынмаган тупас йөз, агачтан юнган кебек күренгән шул йөзгә азрак ямь бирүче җитез, йөгерек күзләр, ялбыр чәч – һич күргән кешесе түгел.* Д.Булатова

2) Киң ябалдашлы һәм куе яфраклы (агач тур.). *Әнә теге ялбыр каенның астында бер вакытта җырлап утырган идем, әнә теге әрәмәнең уртасында утырган юкә агачына без үткән ел умарта күтәргән идек.* М.Гафури. *Биредә якты каен, ялбыр юкә, моңсыл таллар, горур имән, мәһабәт карагайлар юк.* З.Мурсиев

3) Катлауланып торган (болытлар тур.). *Тиеп тора болытларга, Болытлары – ялбыр. Өстәвенә бертуктаусыз Явып тора яңгыр.* Р.Миңнуллин. *Бүген вакыт шуышып кына атлый, Ялбыр болытларны бөркәнеп.* Р.Бикбаев

4) Тырпаеп торган. *Мәхәббәт дигәндә, кәкре аяклы, ялбыр колаклы, табак битле Шиһапның гыйшык тотып йөрүләрен күз алдына китерүе кыен хәзер.* М.Кәрим

**ЯЛБЫРДА́У** *ф.* Тирбәлү, селкенү, чайкалу; селкенеп, җилфердәп тавыш чыгару; селкенгәндә, төрле якларга таралып, җилфердәү. *Чапты алар яшь чакларын уйлап, Ялбырдады җилдә йоннары, Низам эчтән, әкрен генә итеп, Яралылар өчен җырлады...* С.Хәким. *Агачлар ялбырдый*

**ЯЛБЫ́Р-ЙОЛБЫР** *иярт.* Җилфер-җилфер. *Зәлифә ак халаттан бигрәк тә чибәр икән: киеме ялбыр-йолбыр килеп тә йөрми, кайбер хатыннарныкы кебек җөйләре шартларлык тартылып та тормый, ә тап-таман булып, туташның нәфислегенә тап килеп кенә тора.* З.Мурсиев

**ЯЛБЫРЛАНУ** *ф.* Озынаеп, куеланып китү. *Саргылт күн кепкадан кара чәчләре әз генә бер якка чыгып ялбырланган.* Х.Камалов. *Минә каен киткән үрчеп, Тәлгәш-тәлгәш ялбырланган.* И.Киньябулатов

**ЯЛВАРУ** *ф.* Бик нык үтенү, ялынып, түбәнчелек белән сорау. *Әнисе аны тагын оялтырга тырышты, ялынды, ялварды: – Халык төртмә теле белән күз ачырмас. Акылыңа кил, – диде.* В.Имамов. *Кайчакта исә ниләрдер үтенә, ялвара, күңеле нечкәреп, елый да башлый...* З.Мифтахов

**Ялвара башлау** Ялварырга тотыну. *Минә шул чакта, янә миңа карап, яше вә карты сине дә, мине дә дөньяга яраткан бердәнбер Раббыбызга ялвара башлый.* Г.Галиева. *Ул куркуын, каушавын чак-чак басып, Дилүскә үрсәләнеп ялвара башлады: – Дилүс, зинһарлар дип сорыйм, акылыңа кил, исәрләнмә!..* Г.Гыйльманов

**Ялвара бирү** Бернигә карамый ялваруын дәвам итү. *Беребезне дә ишетми, ялвара бирә* ---. М.Вәлиев

**Ялвара төшү** Бераз ялвару; тагын да ныграк ялвару. – *Ялвара төшсәң, ризалык бирмәсме соң, – диде ул аптырагач.* Р.Вәлиева

**Ялварып йөрү** Гел, озак вакыт дәвамында ялвару. – *Кыйна син мине, Төхфәт, үтер... Бәкегә илтеп ташла... Мин гаепле, – дип ялварып йөрде.* Г.Кутуй. *Хәзерге авыл советы председателе әнә, баганаларын да, җепсәлекләрен дә, рәшәткәлек тактасын да үзем табам, эш хакын да түлим, тик коймасын гына коеп бирегез шул зиратның дип, күпме ялварып йөрде.* В.Нуруллин

**Ялварып тору** Әледән-әле яки озак вакыт дәвамында ялвару; хәзерге моментта ялвару. *Кул сузып, ялварып торучылар күренми.* Р.Батулла. *Идәнгә тезләнгән килеш, табактагы балыкка ялварып торучы картын күргәч, ишек катында пәйда булган Фатыйма карчык шундук почмакка посты.* Г.Гыйльманов

**Ялварып утыру** *сөйл. к.* **ялварып тору**. *Аллага ялварып утырырга гына калды микәнни?* Ф.Садриев. *Кәҗәбистәнселәргә, киләчәккә өметләнеп: «Сатып алыгыз безнең җирләрне!» – дип ялварып утырасы гына кала.* Татарстан яшьләре

**Ялварып яту** *сөйл. к.* **ялварып тору**. *Василий 1431 нче елның 15 нче августында, Юрий өч атна соң – 8 нче сентябрендә Сарай шәһәренә таба юлга чыгып, икесе дә Алтын Урда ханының күңелен табар өчен ялагайланып, хан тирәсендәге зуррак түрәләрнең күңелен табарга тырышып, бер елга якын тарелка тотып ялварып яттылар.* Безнең мирас

**ЯЛВАРУЛЫ** *с.* Ялвару катнаш; бик нык үтенүне, ялваруны белдергән. *Шунда колагыма нindидер ялварулы тавыш, кемнеңдер шыңшыганы ишетелде.* А.Хәсәнов. *Бер урында таптанып көтеп торган малай Фаягөлгә ялварулы караш ташлады.* А.Әхмәтгалиева

**ЯЛВАРЫНУ** *ф.* Кабат-кабат, төрлечә ялвару. *Ә түрге өйдә кабат ялварынган тавыш ишетелде: – Җә инде, Гөлүсә матурым, җаныем, былбылым...* Т.Нурмөхәммәтов

**Ялварына башлау** Ялварынырга тотыну. *Кабат ялварына башлады*

**Ялварына төшү** Бераз ялварыну; тагын да ялварыну. *– Бу юлы гына рөхсәт ит инде, – диде ул, ялварына төшеп.* Кызыл таң

**Ялварынып тору** Һәрвакыт ялварыну; сөйләү моментында ялварыну. *Ялварынып торуын ишеттем*

**ЯЛГАМ** *и.* 1) Берәр нәрсәгә ялганган деталь, өлеш һ.б. нәрсә. *Монда да теманың үзенә күрә башлам өлеше, куелыш үзенчәлеге, тәмамлануны күздә тоткан ялгам өлеше була.* Р.Абдуллина

2) *а.х.* Башка үсемлеккә ялганган бөре, ботак һ.б.ш.; *русчасы:* **привой**. *Аның өчен үрчетә торган агачтан чыбыкчалар яки кабыгы белән бөреләр (күзчәләр) кисеп алалар. Бу ялгам дип атала.* Ботаника. *Чәчү, кучереп утырту, агачларга ялгам ясау, үрчетү өчен агач ботаклары кисү эшләрен башкарырга була.* Сөембикә

**ЯЛГАН** *и.* **1.** 1) Бозып күрсәтелгән чынбарлык; хакыйкатькә туры килмәгән факт, мәгълүмат. *Сугыш турындагы китапларны укый башласам, шыр ялган күреп, җенем кабара.* Ф.Яруллин. *Нәтиҗәдә мин, барып, халыкка ялган сөйләргә тиеш.* А.Гыйләҗев

2) Алдау максаты белән хакыйкатькә туры килмәгәнен белә торып әйтелгән сүз. *Кәримә, үзенә һич хас булмаган рәвештә, нечкә тавышы белән кычкырып ук җибәрде: – Ялган, ышанмагыз, ялган бу!* Ә.Еники. *– Ялган, һич ышанма! – диде дуслар.* А.Хәлим

3) Алдау очрагы, алдау гамәле. *Ялган һәм хыянәт ачысыннан сыгылып төшкән ирне «туганнар» да артык үзләрендә тотарга теләмәде.* А.Әхмәтгалиева

**2.** *с. мәгъ.* 1) Чынбарлыкны, хакыйкатьне бозып күрсәтә торган, дөрес булмаган, чын булмаган. *Авыруым турындагы ялган хәбәрне ишетмәгән булсаң, бәлки, килмәгән дә булыр идең.* Р.Батулла. *Нindидер ялган шаһитлар таптырып, өстемнән җинаять эше ачтырды.* Х.Ибраһим

2) Чын булмаган, ләкин чын дип кабул ителгән, шулай күзалланган; алданулы (хис-кичерешләр тур.). *Ялган хисләр, ялган сөюләрдән Йөрәккәем тәмам суынды.* Р.Зәкуан. *Шәрифне яратам дип йөргү ялган хис булып чыкса?* А.Әхмәтгалиева

3) Ясалма; ялгыш караш тудыра торган. *Ялган пафос, ялган батырлык күп булган ул әсәрләрдә, ә кешеләргә дөреслекне белү кыйбат.* Р.Фәйзуллин. *Ялган өмет. Ялган вәгъдә*

4) Кемнедер алдау, табыш алу һ.б.ш. максаттан, тышкы билгеләре белән чын, хакыйкый әйбергә, оригиналга охшатып ясалган. *Сез табышны уртаклашмадыгыз, ялган документка кул куймагач, кем гаепли алсын кешене...* Г.Афзал. *– Ялган акча мондый буламыни?! – диде Шәфи, хихылдап, һәм бер капны аңа сузды.* З.Мәхмүди

5) Ялгыш; дөрес булмаган; көтелгән нәтиҗә бирми торган. *Хәйләкәр төлке аучыны алдап баргандай, аны ялган юлларга да кертеп җибәргәләде.* Ф.Садриев. *Тикшерүне юри ялган юлга алып керергә маташасыз!* Р.Зәйдулла

6) Күренеше генә булган, үз функциясен тулысынча башкармый торган. *Анда аны ялган йозак каршы алды.* М.Хәсәнов. *Ялган йозак кына эленгәние, кул тидерүгә, ачыла да китә.* К.Кәримов

◊ **Ялганга чыгару** Ялган итеп күрсәтү; ялган итеп тәкъдим итү. *Агент аның сөйләгәннәрен берәм-берәм ялганга чыгарып битемә бәрер, дигән шик һаман аны сагайта һәм аның җаенарак ятарга, энәләрен тырпайтмаска мәҗбүр итә иде.* Х.Камалов. *Шулай итеп, аларны ялганга чыгардылар.* Р.Сафин. **Ялганга чыгу** Ялган булуы фаш ителү; дөрес булмау; алай булып чыкмау. *«Матур урыннар күрсәтәм» дип шапырынды да бит, менә сүзе ялганга чыкты.* Г.Бәширов. *Болар да килгән булгач, туры элемтә дигәннәре ялганга чыкмый, димәк.* В.Имамов.

**Ялган капчыгы** Ялганларга бик оста һәм һәвәс кеше; оста ялганчы. *– Пётр, син – ялган капчыгы, яле, менә хәзер безне тагын бер алдалап карачы? – диделәр.* Т.Әйди. *Ә син, ялган капчыгы, учакны дөрләт.* Сөембикә

**ЯЛГАНЛА́У** *ф.* Ялган сөйләү, алдау. *Хатын иртәрәк кайтырга кушкан иде, дип ялганлады Хәмит.* Ә.Сафиуллин. *Ялганлый Юныс, күрәләтә кара яла яга.* М.Маликова

**Ялганлап алу** Берара, аз гына ялганлау. *Биредә ант кабул иткәнчегә кадәр, дип, ялганлап алалар.* Кәеф ничек?

**Ялганлап җибәрү** Тиз генә, җиңелчә генә ялганлау. *Шуңа малайлар кирәкерешкә: – Хуҗа абзый, берәр нәрсә ялганлап җибәр әле, – диләр.* Ф.Яруллин. *Син дә бераз ялганлап җибәр шунда, тизрәк дан казанырсың.* Р.Нуруллин

**Ялганлап йөрү** Гел ялганлау; озак вакыт дәвамында ялганлау. *Карт башы белән ялганлап йөргәне өчен битенә төкерер идем, бәхете, өйдә юк икән.* Т.Гыйззәт

**Ялганлап калу** Ялганларга өлгерү. *Исереп, өстәл астына ауганчы ялганлап кал ---.* Г.Ибраһимов

**Ялганлап карау** Ялганларга тырышу. *– Юк, кызый, яшермә, яшермә, сөйгән егетең дә, мәсәлән, мин сүккәч, тилиграм дип ялганлап караган иде дә... юк, бабагызны, мәсәлән, алай алдый алмассыз, – диенә иде.* Ф.Әмирхан

**Ялганлап килү** Күптәннән, әллә кайчаннан бирле даими ялганлау. *Әмма әнинең тормышы турында ялганлап килергә мәҗбүр булды Алинә.* Сөембикә

**Ялганлап кую** Көтмәгәндә, тиз генә ялганлау

**Ялганлап ташлау** Ашыгу, ялгышлык һ.б.ш. белән ялганлау. *– Андагы чигешләр, бизәкләрне... ни... әнием күчереп алмакчы иде! – дип, үзем дә сизмичә ялганлап ташладым.* Р.Батулла

**Ялганлап тору** Әледән-әле ялганлау; хәзерге моментта ялганлау. *Телемне әрәм итеп ялганлап торам менә!* Г.Бәширов. *Сезнең алда да ялганлап торгач, мин аның белән бүтән бер көн дә эшләячәк түгел.* В.Нуруллин

**Ялганлап утыру** *сөйл. к.* **ялганлап тору**. *Карт башыгыз белән ялганлап утырасыз!* Р.Зәйдулла. *Соң бу легенданы мин балыкчылардан ишеткән идем, ә син, төшемә керде, дип ялганлап утырасың.* З.Мурсиев

**Ялганлый башлау** Ялганларга тотыну. *Ялганлый башласа, аның йөзе*

*кызара, һәм барыбер тотыла.* Г.Кутуй. *Ирексездән ялганлый башласам да, әнием барыбер сизәчәк һәм гафу да итмәячәк.* Ә.Еники

**Ялганлый бирү** Бернигә дә карамый ялганлау; ялганлавын дәвам итү. *Шулай булса да, ул кыенсынмый, һаман килеп кергән бер кешегә ялганлый бирә.* Г.Бәширов. *Ә менә Мостафин каш астыннан гына елмаеп, үзенчә: «Әйдә, әйдә, ялганлый бир тыңлаучы барда», – дип әйтә сыман иде.* Ф.Зыятдинов

**Ялганлый төшү** Бераз гына ялганлау; тагын да күбрәк ялганлау. *Тизлеге харап: ун адымга ким дигәндә ун минут узгандыр, чак кына ялганлый төшсәң.* Ә.Баян

**ЯЛГАНЛАШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **ялганлау**. *Ай-һай-һай! Ярый, ялганлашмыйк.* М.Хәбибуллин. *Безнең өйдә алдашу-ялганлашу, бер-береңә кырын карау юк.* Сөембикә

2) *ялг. к.* **ялганлау**. *Белер хәлем юк: кайсы ялганлаша.* Р.Ханнанов. *Теге нәмәстә: «Сәгатьне мин сатып алдым! Акча да түләдем», – дип, күзгә карап ялганлаша бит.* Р.Мулланурова

**Ялганлаша башлау** Ялганлашырга керешү. *Бер-берсенә ялганлаша башлаганнар икән*

**Ялганлаша тору** Билгеле вакыт ялганлашу. *Ялганлаша торгач, күзләрем атылып чыга язды.* Р.Гаязетдин

**Ялганлашып йөрү** Озак вакыт дәвамында ялганлашу. *Ә нишләп сез ялганлашып йөрисез? Улыгыз сукканны, киленем кыйнады, дип киләсез?* Гөлшәһидә

**Ялганлашып тору** Һәрвакыт ялганлашу; әле хәзер ялганлашу

**Ялганлашып яту** *к.* **ялганлашып тору**. *– Ялганлашып ятсаң, хаҗи абзыеңның каргышы төшәр башыңа, бел аны! – диде.* Р.Максутов

**ЯЛГАНЛЫК** *и.* 1) Дөреслеккә туры килмәү хәле; ялган булу. *Давыд берике сүз белән хәбәрнең ялганлыгын аңлатты.* Г.Ибраһимов. *Шахтёр, башка тыңлаучыларга күзен кысып, сүзнең ялганлыгын белгертеп ала.* А.Алиш

2) *ялг. к.* **ялган 1**. *Чөнки күз буярга тырышу, ялганлык чанасына утыру, төлке кебек койрык болгап маташу корымы аның намусына аз гына да буялмаган әле.* С.Поварисов. *Ихласлыкны тапмый кешеләрдән, Җаның гаҗизләнеп калганда, Ялганлыкны белмәс саф чисталык Табарсың син сабый балаңда.* Ф.Дәүләтгәрәева

**ЯЛГАНМА** *и.* **1.** 1) Ялганган әйбер; берәр зур нәрсәнең ялганган өлеше. *Насослар эш басымын бирә башлагач, трубопроводның бер ялганмасы чималны тышка чыгара башлады.* Казан утлары. *Түбән Вартадан 62 чакрым ераклыкта Пурпе – Самотлор магистраль нефтьүткәргеченең беренче ялганмасы эретеп ябыштырылды.* Яңарыш

2) *а.х.* Башка үсемлектән алып ялгау өчен файдаланылган тамыр һәм кәүсә өлешеннән гыйбарәт үсемлек; *русчасы:* **подвой**. *Ялгамны ялганмага – тамыры булган икенче үсемлеккә – сабакларын бер-берсенә туры китереп тоташтыралар һәм киселгән урынны махсус материал белән тыгыз итеп бәйләп куялар.* Биологияч

**2.** *с. мәгъ.* Ялганган, кушылган. *Әлеге сыйфатларның барысы да ялганма үсентегә күчә, кыярның тәме исә шул ук кала.* Якты юл. *Ялганма ботак. Ялганма чәч*

**ЯЛГАНМАЛЫ** *с.* 1) Ялганмасы булган. *Ялганмалы алмагач. Ялганмалы чия агачы. Ялганмалы җиң*

2) *лингв. к.* **агглютинатив**. *Кушымчалар – безнең бер татар телендә генә түгел, бәлки барлык ялганмалы телләрдә дә иң әһәмиятле урын алган морфологик элементларның берсе.* Х.Бәдигый. *Тик И.Гиганов кына үз грамматикасында, рус теле белән чагыштырып, татар теленең байтак үзенчәлекләрен дөрес билгели алган: татар телендә «сүзләргә кушымчалар ялгана» дигән искәрмәсе белән әһәмиятле бер үзенчәлеккә – татар теленең ялганмалы табигатенә игътибар итә.* Татар грамматикасы

**ЯЛГАНМАЛЫК** *и. ялг.* 1) *к.* **ялганмалылык**. *Г.Алпаров «Татар теленең ялганмалык табигате турында» (1927) исемле мәкаләсендә сүз ясый торган, сүз төрләндерә торган һәм бәйләгеч кушымчаларны бүлеп чыгара.* Р.Фәттахова. *Моңарчы да тупланган фәнни күзәтүләргә, тәҗрибәгә таянып әйтә килдек, бүген дә кабатлыйбыз: алфавитның һәм аннан аерылгысыз орфография-орфоэпия-пунктуация кагыйдәләренең хәзерге иҗтимагый сөйләм таләпләренә ни дәрәҗәдә җавап бирүе, камил булуы аларның татар теленең төп законнарына (сингармонизм, басым, ялганмалык, тыныш-аһәң һ.б.) нигезләнүенә бәйле.* Ватаным Татарстан

2) *а.х.* Күчереп ялгау өчен әзерләнгән чыбыкча, бөре һ.б.ш. материал. *Алмагач өчен ялганмалыклар әзерләү*

**ЯЛГАНМАЛЫЛЫК** *и. лингв.* Агглютинативлык. *Сүзтезмәне язганда да әдәби тел нормалары, аның эчке законнары (сингармонизм, басым, ялганмалылык, тәртип, аһәң һ.б.) сакланырга тиеш, ә аларны чын-чыннан гамәлгә ашыру, үтәү мөмкинлеге синтагманы әйтү барышында төгәлрәк саклана.* И.Низамов. *Автор бу уңайдан төрки телләр өчен хас күп кенә лексик, фонетик һәм грамматик закончалыкларны күрсәтеп үтә: сингармонизм күренеше, ялганмалылык, родларның булмавы, тартым категориясе булу, ярдәмче фигыльләрнең зур урын тотуы, гомумтөрки лексик фондның барлыкка килүе, төрки сөйләмнең, сүз тәртибенең үзенчәлекле төзелеше һ.б.* Фән һәм тел

**ЯЛГАНУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **ялгау** (*1 мәгъ.*). *Торбага торба ялгана, көнгә көн тоташа торгач, Тугаш бабай күрсәтергә вәгъдә иткән бәйрәм дә сиздермичә генә килеп җитте.* Ә.Баян. *Паровоз, безнең хәлне аңлагандай, авыр пуфылдап куя, рельс белән рельс ялганган җирдә вагоннар чак кына сөрлеккәндәй акрынаялар да кабат алга тартылалар.* Ф.Хуҗин

2) *мед.* Тоташу, берегү, берегеп үсү. *Сынган сөяк ялгана, күңел сының сынмасын, ди, әнә халык әйтә.* Р.Төхфәтуллин. *Кулының сынып ялганган булуына карамастан, Газдал аңа эш кушты да эш кушты.* Ф.Садриев

3) *мед.* Йомылу, бетәшү (яра тур.). *Аның бит башындагы ярасы инде күптән төзәлде, ләкин яңагындагы ярасы һаман төзәлеп, ялганып җитми әле.* А.Шамов

4) *бот.* Башка үсемлектән күчереп утыртылган бөре, чыбыкча һ.б.ш. тоташу, кушылу. *Ә агачта исә Совет – Германия дуслыгына егерме ел тулу хөрмәтенә ялганган ботак үсә.* М.Гәрәев. *Ялганган бөрене целлофан пакет белән төреп, «теплица» ясарга киңәш ителәр.* Кәеф ничек?

5) Булганына өстәп, башка материаллар кушып тагын да озынайтылу (чәч, тырнак, керфек һ.б.ш. тур.). *Регинаның ялганган тырнаклары гына аны бераз сискәндереп җибәрде.* Ф.Яруллин. *Ялганган чәч – Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән сөенеч түгел, бәлки кешенең үз наданлыгы белән уйлап чыгарылган яманлыгы гына.* Ф.Яхин

6) Хәбәрләшергә мөмкинлек туу, теге яки бу элемтә чарасы ярдәмендә

бәйләнешкә керү; тоташу. *Ул арада элемтә өзелеп китте, кабат ялганды һәм елау катыш: «Улым... улым...» – дигән сүзләр ишетелде.* Ф.Садриев

7) Тоташу; кушылу (электр, интернет һ.б.дан файдалану тур.). *Ут сүнүгә, кабинетыма майор атылып килеп керде, мин подвалга төшеп киттем, ә Рабит абыең, челтәргә ялганган ватык чәйнекне аласы барын сылтау итеп, үз кабинетына олакты.* Ф.Бәллүр

8) *лингв.* Сүзнең тамырына, нигезенә яки кушымчага кушылу. *Бер очракта сүзләрнең әүвәлге әйтелешендәге кайбер авазлар, иҗекләр төшеп калса, икенче бер очракта төп мәгънә белдерүче сүзләргә өстәмә иҗекләр ялганырга мөмкин.* Н.Фәттах. *Әйтик, көндәлек аралашуда татарлар рус алынмаларын татар сүзләренә генә ялганырга тиешле кушымчалар өстәп куллана.* Р.Рахман

9) *күч.* Кайсы яктан булса да берәр нәрсә белән бәйле булу, шуңа нигезләнү, шуннан килеп чыгу, шуңа тоташу. *Бик тә озын гомерле, хәтта безнең көннәргә үк килеп ялганган проблема бу.* М.Вәли-Барҗылы. *Бизнә – мәшһүр Шиһабетдин Мәрҗанинең дә нәсел тамыры ялганган авыл икән.* Безнең мирас // Берәр кеше белән рухи бәйләнештә булу. *Истәлегем – сиңа ялганган.* Р.Әхмәтҗан. *Ә минем җырлы бу халәт синең җанга ялганган!* Р.Гаташ

10) *күч.* Бер-бер артлы булу; берсеннән соң үк икенчесе башлану. *Яңа даирәне үзләштерү, хисапсыз очрашулар, берсе икенчесенә ялганган командировкалар...* Н.Мириханов

11) *күч.* Сүз, әңгәмә, эш-хәл эзлекле булу, бер-бер артлы берегеп, дәвам итеп тору. *Бераз дәшми барганнан соң, сүз тагын ялганды.* Г.Кутуй. *Әңгәмә үз җае белән көндәлек яшәешкә, шәхси тормышка килеп ялганды.* М.Маликова

**Ялгана бару** Эзлекле рәвештә, һаман ялгану. *Буыннар шулай өзелеп-өзелеп ялгана бара!* Ш.Галиев. *Шулай очы очка ялгана барды.* Ф.Җамалетдинова

**Ялгана башлау** Ялгануга таба бару; ялгану билгеләре күренү, сизелү. *Аяклары сөяк ялгана башлаган урыннан шешеп чыга.* Ә.Галиев. *Их, өзеләр бит әле ялгана башлаган язмыш җебен.* М.Галиев

**Ялгана тору** Даими, эзлекле рәвештә ялгану. *Гауга кухнядан караваткка, караваттан аш-су тирәсенә ялгана торды, өзелмәде.* А.Гыйләҗев. *Сүзгә сүз ялгана торгач, әңгәмә әкрен генә җанланып китте.* Р.Габделхакова

**Ялгана төшү** Беркадәр ялгану; тагын да яхшырак ялгану. *Әлегә иртәрәк икән, сөякләре ялгана төшкәнне көтәләр.* Р.Вәлиева

**Ялганып бетү** Тулысынча ялгану; барысы да ялганган хәлгә килү. *Кайберәүләр арасында кат-кат ялганып беткән төенле җепләр, я тегәрҗеп, кәтүк җепләре генә.* Ш.Галиев. *Шулай да кайбер мәгълүматларның очы очка ялганып бетми.* Р.Мостафин

**Ялганып җитү** Тиешенчә ялгану; тулысынча ялгану. *Ләкин барыбер сүзгә сүз ялганып җитми, күңелдәге теге олы яңа хис-тойгы, әле уңайсыз күз карашы булып, әле урынсыз әйтелгән сүз булып, кабат тышка бәреп чыга, бу матур, бәхетле һәм серле-илаһи дөньядан читкә тайпылырга мөмкинлек бирми...* Г.Гыйльманов. *Шәмсүн Рәфиснең бу халәтен сизде һәм моны кырыс, туры сүзле булып маташкан элекке дустын җиңүе итеп кабул итте, шуңа күрә, ике арадагы мөнәсәбәтләр юньләп ялганып җитмәгәнлектән, урынсыз һәм вакытсыз уенын туктатырга булды...* А.Вергазов

**Ялганып калу** Ялганырга өлгерү. *Сөяге шул вакытта ук ялганып калган, диләр.* М.Вәлиев

**Ялганып килү** Акрынлап ялгану, ялгануга якынлашу. *Димәк, җөе ялганып килә.* Н.Әхмәдиев. *Ул хатларга каршы безнең кызлар бик теләп җавап язалар, кайсыберләре арасында хәтта якын дуслык җепләре дә ялганып килә бугай.* С.Сабиров

**Ялганып китү** Берәр тәэсирдән, вакыйгадан соң ялгану. *Икенче көнне әнисе белән аның арасында шундыйрак сүз ялганып китте.* Н.Фәттах. *Коръән аятьләренә үзләре иҗат иткән тезмә юллар да ялганып китә, дөнья хәлләре дә.* К.Миңлебаев

**Ялганып кую** Алдан ук ялгану; тиз арада ялгану; ялганган хәлгә килү. *Аның ярдәмчеләре күз иярмәслек тизлектә элеватор, автоматик ачкыч, трос ише нәрсәләр белән эш итә, һәм корыч колонна торбалары, теш камаштырырдай каты һәм ачы шыгырдап, берсе икенчесенә ялганып куя.* Э.Касыймов

**Ялганып тору** Вакытлыча ялганган булу; бер-бер артлы ялгану; даими ялгану. *Тормыш мәшәкатьләре берсе артыннан берсе туып, үзара ялганып тора.* Н.Әхмәдиев. *Нindидер мизгелдә иреннәр бер-берсенә ялганып торды.* Х.Камалов

**ЯЛГАНЧЫ** *и.* **1.** Ялган сөйләүче, ялган сөйләү гадәте булган кеше. *Авылда аның ялганчы дигән даны чыккан иде.* Т.Миңнуллин. *Каршы әйтеп, күңелен төшерәсеңме, ризалык биреп, ялганчы буласыңмы?* Р.Рахман

**2.** *с. мәгъ.* 1) Ялган сөйли торган; алдый торган. *Буш, ялганчы кешеләр минем дошманыма әверелер.* А.Хәлим. *Айрат беренче мәртәбә халык зирәклегенә таң калды – хәтерендә балачактан ялганчы көтүче турындагы әкият яңарды.* Х.Ширмән

2) к. **ялган** (*6 мәгъ.*). *Мунчаның өйалдына эленгән ялганчы йозагын ачып эчкә узды, андагы керосин лампасын яндырып, ләүкәдәге әйберләрне алып куйды да, утны сүндереп, шунда ятты.* Ф.Садриев. *Күгәреп беткән ялганчы йозакны алып, ишеген киң ачып, йорт ияләренә шаулатып сәламен биреп, түргә узгандыр.* Г.Габидуллина

◊ **Ялганчы чокыры** Муенның арткы өлешендәге батынкы урын. *Һашимнең куллары салынды, башы иелде, ялганчы чокыры йодрык сыярлык булып тирәнәйде.* Р.Зарипов. *Абыйсыннан калган кыршылган сумкасын асып барганда, каршысына без юлыксак, безгә йодрык сыешлы йөнтәс ялганчы чокырын гына күрсәтеп узып китәр иде.* Р.Төхфәтуллин

**ЯЛГАНЧЫЛЫК** *и.* Ялганчы булу үзлеге; ялган сөйләү гадәте. *И егет, ирләр арасында ялганчылык – гаеп эштер.* К.Насыйри. *Син теләсәң ничаклы килештереп сөйләмә, әгәр синең сөйләгәннәреңнең ялган икәнлеген белсәләр, хәзернең эчендә синең маңгаеңа ялганчылык мөһере басалар да куялар.* Гали Рәхим

**ЯЛГА́У** *ф.* 1) Бәйләп, ябыштырып, тегеп һ.б.ш. юл белән әйберләрне яки шуларның кисәкләрен бер-берсенә беркетү, кушу, тоташтыру. *Дүрт сәгать чамасы туктаусыз дәвам итте операция – төзәттеләр, ялгадылар һәм ямадылар да ямадылар.* Р.Мөхәммәдиев

2) *сөйл.* Берәр гомуми системага, челтәргә тоташтыру; кушу; җибәрү (электр тогы, радио, интернет кебек). *Баганадан тимерчыбык җибәреп, ток ялгадылар.* А.Алиш. *– Теге аппаратыңны параллель итеп ялгадыңмы әле? Тоташтырган өчен йөз сум түлисе була бит, – дип шаяртты.* Т.Нәҗмиев

3) Берәр гомуми системага тоташтырылган прибор, җайланма һ.б.ш.ны

эшләтеп җибәрү, кабызу. *Аны калын телем итеп киселгән икмәгенә кисәкләп тезеп, егет чәйгә утырды һәм радиосын ялгады.* Ф.Яхин

4) Телефон челтәренең ике абоненты номерын бер-берсе белән тоташтыру; алар арасында телефон элемтәсе булдыру. *Бүген элемтә бик начар булды: бер ялгадылар, бер өзделәр...* Кызыл таң

5) *махс.* Сыйфатын яхшырту, үзгәртү өчен бер үсемлекнең чыбыкчаларын яки бөреләрен икенче үсемлеккә беркетеп, тоташтырып кую. *Менә шуңа мин бик затлы алма сортын ялгадым.* Т.Нурмөхәммәтов. *Үзен «мичуринчы» дисәң дә һич артык булмас: бер алмагач кәүсәсендә, ботакларын ялгап, бернichә сорт алма үстерә ул!* Кызыл таң

6) Сөйләмдә бер фикерне, мәсьәләне икенче фикер, мәсьәлә белән бәйләү. *Шәһәр активы Казан хуҗалыгының торышын тикшергәндә, Валериан Леопольдович, сүз алып, шәһәр транспортын, шуңа ялгап, шәһәр башлыкларын тетеп ташлады.* А.Гыйләҗев

7) Озынрак, куерак, матуррак итү өчен, булганына өстәү; озынайту (чәч, керфек, тырнак һ.б.ш. тур.). *Регинаның ялганган тырнаклары гына аны бераз сискәндереп җибәрде.* Ф.Яруллин. *– Ялгамагыз, чәч ялгарга теләгән кешеләрне Аллаһы Тәгалә ләгънәт кылды, – дигән пәйгамбәребез.* Ф.Яхин

8) *куч.* Хәреф яки сүзләрне тоташ әйтү, бер-берсенә бәйләп, кушып уку. *Бер битен укып, икенче биткә күчкәч, Габдулла өзелеп калган җөмләне ялгый алмый тынып калды.* Ә.Фәйзи. *– Менә сиңа Кыш бабай һәм Кар кызы! – диде ул, сүзен сүзгә ялгый алмый.* Д.Гыйсметдин

9) *күч.* Сүзгә, әңгәмәгә катнашып, кушылып, өстәп әйтү яки алдагы сөйләүченең фикерен дәвам иттерү. *Ләкин Зәлиянең сизгер карашы барысын да үтәли күреп, сизеп торган диярсең, ул үзенең сүзен нәкъ шуңа китереп ялгады.* Р.Вәлиев. *– Һушы китте бит безнең ат-ат булып уйнаганга, – дип сүзне ялгады Гайнулла, – аларда бар эш тә техникага җайланган, малайлар.* К.Кара

10) *күч.* Кушып җибәрү, берләштерү. *Минемчә, дүртенче күренешне бишенче күренешкә ялгарга кирәк булыр.* М.Җәлил. *Шуңа күрә бу төр әсәрләрне, алардагы аерым күренешләрне механик рәвештә тегендә-монда ялгарга тырышу – күркәм гамәл түгел.* Х.Миңнегулов

11) *күч.* Мөнәсәбәтләрнең яхшыруына, рухи бәйләнешнең якынаюына сәбәпче булу; бәйләү; дуслаштыру, якынайту. *Бүгенгесе көндә, белеп кал, Әсфан белән безнең араны Фәүзия ялгады.* А.Гыйләҗев. *Казан йортта сезнең белән туганлык җепләре ялгап яшәргә атлыгып торучыларны санап бетергесез.* В.Имамов

12) *күч.* Нәрсәнедер бер-бер артлы эшләү, берсе артыннан ук икенчесен эшләү; кушып китү. *Ә Асия бер көйгә икенчесен, өченчесен ялгап, һаман уйный бирде.* Г.Әпсәләмов

**Ялгап алу** Кыска вакыт эчендә, тиз генә ялгау; вакытлыча ялгау. *Берәмберәм исәнләшеп, Габдрахман белән сүз ялгап алды: – Җә, эшләрең ничек?* Г.Ибраһимов. *Чыбыкларны ялгап алу*

**Ялгап бару** Эзлекле рәвештә, рәттән ялгау; бер-бер артлы ялгау. *Врач та аны ташлап чыгарга уңайсызлана, берике сүз белән генә, җайлап, сөйләшүне ялгап бара иде.* А.Гыйләҗев. *Әсәрдә укучы күз алдыннан язучының оста каләме белән чылбыр боҗралары шикелле бер-берсенә матур итеп ялгап барган күпсанлы вакыйгалар үтә, алар эчендә төрле-төрле персонажлар калкып чыга.* М.Хәсәнов

**Ялгап бетерү** Бөтенләй, ахырына кадәр ялгау. *Ялгап бетергәч, ике башыннан тотып тартты да түгәрәкләнеп тезелгән иптәшләренә күрсәтте: – Күрдеңме?* Г.Сабитов. *– Нинди бала? – дип, Алмаз фикер очын ялгап бетерә алмаган төстә карады.* Х.Камалов

**Ялгап бирү** Башка кеше өчен ялгау. *– Әй-й, җаныем, ирем бигрәк юньсез инде, шушы үтүкнең чыбыгын гына ялгап бирә алмассың микән? – ди.* Аманулла

**Ялгап җибәрү** Җае белән ялгау; тиз арада ялгау. *Кергәннән бирле кунак кыздан ул да күзен алмый, сүз ялгап җибәрергә җай гына көтеп утыра иде.* Г.Бәширов

**Ялгап йөрү** Гел ялгау; озак вакыт дәвамында ялгау. *ФЗӨ мәктәпләренә җибәрелеп, 16 яшьтә әти-әнидән, туганнардан читтә, чабатадан, тездән су ерып, шахтада электр чыбыклары ялгап йөрүләр дә җиңел булмады.* Безнең гәҗит

**Ялгап карау** Ялгарга тырышу; белү, сынау өчен ялгау. *Операциясез генә ялгап карыйбыз дип, кулга укол кадый һәм – а-а-а!* Э.Закирова. *Аларны, бәлки, корама юргандай итеп, очын-очка ялгап карарга булыр?* Г.Якупова

**Ялгап китү** Ниндидер бер моменттан башлап ялгау. *– Әле моны Гриша да белми, – дип, өзелгән сүзен ялгап китте ул бераздан.* М.Әмирханов

**Ялгап кую** Тиз генә ялгау; алдан ялгау; бер тапкыр яки кинәт ялгау. *Сузып әйтелгән сүзенә үзе ялгап та куйды: – Берәр җиргә барып утырсаң иде.* А.Алиш. *Табиб алар арасындагы өзелгән җепләрнең бер нечкәсен генә булса да ялгап куярга омтылыш ясагандай иткән иде.* М.Маликова

**Ялгап тору** Даими ялгау; озак вакыт ялгау; әле, хәзер ялгау. *Үткәннәрнең моңлы авазын бүгенге белән ялгап торган җанлы күпер кайда өзелгән?* А.Вергазов. *Ерак-еракларны ялгап тора Безнең буыннарның бәйләнеше.* Л.Шәех

**Ялгап утыру** *сөйл. к.* **ялгап тору**. *Әйтерсең ки шул көйләр бүген дә дәвам итә – Гатуф атлы Бикимов иске хатирәләргә охшаган көйләрен бербересенә ялгап утыра...* Ә.Баян. *Үткен сатирасы, иркә юморы, тирән лирикасы белән татарны таң калдырган халык шагыйре Гамил Афзал, төпле фикерле, тарих кыяларын бүгенгегә ялгап утырган галим Альберт Фәтхи – шушы авыл балалары.* Р.Мәрданов

**Ялгап яту** *сөйл. к.* **ялгап тору**. *Көннәрдән бер көнне Сәрвәр, иртән үк килеп, сабанның сынган төрәнен ялгап ята иде, алачыкка, сулуы кабып, Гөлнур йөгереп керде.* К.Тимбикова

**Ялгый башлау** Ялгарга тотыну. *Өзелгән урын ерак түгел иде, әмма ялгый башлагач, телефон чыбыгының бер метр чамасы кыскарганлыгы беленде.* Г.Әпсәләмов. *Мин телефонның шнурын ялгый башладым.* Ф.Яруллин

**ЯЛГАУЛЫ** *с.* Беркетелгән, тоташтырылган, кушылган; ялганган, ялгавы булган. *Ә син аяк өстендә ерак басуга килгәнсең, кулыңда әллә ничә ялгаулытөенле дилбегә.* Ш.Галиев. *Ялгаулы пыяла. Ялгаулы тукыма. Ялгаулы җиң*

**ЯЛГАУЛЫК** *и.* Ялгау өчен әзерләнгән материал. *Яңа ялгаулык*

**ЯЛГАШ** *и.* Тагарак. *Ул өенә кереп киткәч, ялгаш кырыена чүгәләдем дә, тегенең тавыкларга дигән бәрәңгесен тизәкләрдән аерып ашарга тотындым.* Н.Кәримова. *Юынырга кулай булсын өчен, кое янына өр-яңа агач ялгаш әмәлләде.* Г.Гыйльманов

**ЯЛГЫЗ** *с.* **1.** 1) Берүзе булган, иптәшсез. *Хөршидәттәй ялгыз түгел, олы якта, самавыр янында, бер ят әби дә утыра.* А.Тимергалин. *Үткән көз*

*анда, Саескан тавы кичүендә, соңгы паромга ялгыз аккош очып кунды.* Н.Гыйматдинова

2) Башкалардан аерым урнашкан, бер генә булган. *Яшенне генә уздырмаган ул ялгыз агач, адәм баласының хәсрәтен дә җиргә тапшырып торган.* М.Мәһдиев. *Һавада тибрәлеп калган ялгыз яфракның нидер эзләп тилмерүен, бәргәләнүен күрәм!* А.Әхмәтгалиева

3) Гаиләсез; өйләнмәгән, буйдак, хатынсыз; кияүгә чыкмаган, ирсез; тол. *Ялгыз хатынга ике баланы аякка бастыруы җиңел түгел бит инде.* М.Кәбиров. *Карале, Зилия, син дә ялгыз, мин дә ялгыз, дигәндәй.* Э.Яһудин

4) *тар.* Эшчәнлекне үзе генә алып бара торган; күмәк хуҗалыктан читтә калган, аерым. *Без мондый үти алмаслык налоглар белән ялгыз хуҗалыкларны аяктан екмаска тиешбез.* Һ.Такташ. *Башында көн саен мең төрле кызыклы уй, хыял туып тора торган егетне, Алма апа белән ялгыз хуҗалыкчы булып, үз яшьтәшләре – комсомоллардан көлдереп йөрү туйдырган.* Г.Ахунов

5) Балалардан, туганнардан, якыннардан башка үтә торган; гаиләсез. *Ялгыз тормыш бик кыендыр бит.* Ф.Садриев. *Ялгыз картлык кичерүче кеше ни кылмас та, ни әйтмәс, һушы да бетеп бара торгандыр инде.* М.Кәбиров

6) *сөйл.* Бер кеше өчен генә билгеләнгән. *Бу – төрмәдәге ялгыз камера белән бер: утырма да, ятма да, каккан казык кебек басып тора бир.* С.Поварисов. *Рөстәм Мингалим Суматрада иҗат командировкасында, чит илдәге этләрнең ялгыз бүлмәдә яшәү шартларын өйрәнә...* Р.Батулла

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Үзе генә, берүзе, башкалардан аерым. *Олыгайган кешенең болай ялгыз йөрүенә гаҗәпләндем.* А.Тимергалин. *Соңыннан тын урамнардан берүзем ялгыз кайттым.* М.Маликова

2) Икәүдән-икәү, чит кешеләрдән башка. *Нигә әле ата кеше аны кызы белән ялгыз калдырырга тырыша?* А.Гыйләҗев. *Ничек тә сезнең белән ялгыз каласым килде.* Аманулла

3) Үзе генә; парсыз булып, хәләл җефетсез килеш. *Ләкин яшь галим аны ялгыз калдырып китеп барган иде инде.* М.Маликова. *Нияз өйләнә алмас инде, ялгыз калыр, дип бик борчыла идек.* М.Әхмәтшина

4) Үзе генә, кешедән башка, ярдәмчесез. *Шул вакытта урамнан, су буйларыннан ялгыз җырлап кайтучыларның тавышлары ишетелә.* М.Мәһдиев. *Ялгыз биеп, җәя-кылыч һөнәрләре күрсәтеп, Ана алдына килеп тезләнә.* Р.Батулла

**3.** *и. мәгъ.* 1) Гаиләсез кеше (әти-әнисез, баласыз, өйләнмәгән, буйдак һ.б.ш. тур.). *Байлар – байлыкларын югалтудан курыккан, ярлылар – ярлылыкларына кимсенгән, парлылар – ялгыз чакларын сагынган, ялгызлар – үз тиңнәрен таба алмаудан зарланган.* Ф.Яруллин. *Нәсимә дә, Шамил дә – ялгызлар.* М.Вәлиев

2) *тар.* Аерым хуҗалык белән яшәгән, күмәк хуҗалыкка кермәгән кеше; *русчасы:* **единоличник**. *Билгеле, кырдан носилкалар белән эшләп үлгән колхозникларны ташый башласалар, ялгызлар башларын кашу гына түгел, колхозга гомергә керәселәре юк.* Һ.Такташ

3) Камерада үзе генә утыручы кеше. *Добров шунда ике ай ялгызлар камерасында «кунак» була, кыйнаулары өчен аңардан берәү дә гафу үтенми, депутатның ачлык игълан итүенә дә төкереп кенә карыйлар.* Т.Әйди

4) Тормыш иптәшен яратмаган, аның белән рухи якынлыгы булмаган кеше. *Әллә син хатыннары бар кешеләрнең барысын да бәхетле дип беләсеңме? Алар парлы ялгызлар.* А.Нәҗми. *Парлы ялгызлар – гаиләле ялгызлар да күбәя.* Н.Шәрифуллин

◊ **Ялгыз башы** Берүзе, үзе генә. *Ничә еллар инде Фәһимә, әнисе һәм бердәнбер баласы өчен борчылып, ялгыз башы гомер итә.* Л.Ихсанова. *Әлфия апа, ялгыз башы Актаныш тавының башына менеп, түбәнгә – Актанышка карап озак тора.* Р.Батулла

**ЯЛГЫЗАК** *и.* **1.** 1) Парсыз, ялгыз кеше; гаиләсез кеше. *Яшьлек бит: өчебез дә ялгызак, гаиләбез дә юк инде.* Л.Шагыйрьҗан. *Заводта утыз ел эшләп, дистә еллар буе чират торса да, ялгызакның сирәгенә хөкүмәт фатиры тәти, чөнки шул ук чиратта ишле гаиләләр күп бит.* М.Маликова // Парсыз, ялгыз җан иясе. *Аккошларның берсе – ялгызагы – мине кочаклады хәтта, анакай, кочаклады.* М.Хәбибуллин

2) Туган-тумачасы, гаиләсе булмаган кеше; япа-ялгыз кеше. *Туган иленнән читтә каңгырып яшәргә мәҗбүр ителгән ялгызак үз хәсрәте белән кыр казлары арасында якынлык таба, эчке охшашлык сиземли.* Т.Галиуллин. *Кыйммәтле дәвалану курслары алырга хәленнән килми – ялгызакның-ялгызагы икән.* Сөембикә

3) Билгеле бер вакытта, урында үзе генә, иптәшсез, ярдәмчесез булган кеше. *Үзем кебек каршылаучыларны да, вагоннан төшкән якыннарын да, аларның чыр-чу килеп күрешүләрен дә күздән кичерәм; як-якларына карангалап, якыннарын күрмәгәч, тыныч кына кайту ягына юлланучы ялгызакларны да абайлап торамын.* К.Миңлебаев. *Ялгызак әллә ничә капчык көмешне завод каравылына сиздерми яшереп алып чыга алмас.* Т.Әйди

4) Билгеле бер урында яки вакытта ялгыз, үз ишләреннән башка булган җан иясе. *Бер үк төрдәге хайваннарның (әйтик, бу очракта маймылларның) күрше төркемнән аерылып чыккан ялгызаклары яңа төркемгә кабул ителергә мөмкин, ләкин төрдәш күршеләр күпләп килә-нитә калса, ике төркем арасында ызгыш-талаш барлыкка килә.* Н.Фәттах // Билгеле бер җирдә үзе генә булган нәрсә. *Каян башлана торгандыр бу дала ялгызагы [Чагала елгасы]?* И.Салахов

5) Бердәнбер, бер генә булган зат, бердәнбер бала. *Исме Сәрби икән, Аклар аткан ялгызагын – үсмер Һидиятен.* М.Җәлил. *Чынында исә бала ялгызак булып үсте, ялгызлык аның юлдашына әйләнде.* Х.Ибраһим

6) *тар.* Аерым хуҗалык булып яшәүче; күмәк хуҗалык әгъзасы булмаган кеше. *Күп булса унлап ялгызак үзеннән таләп ителгән капчык-капчык ашлыкларны җыеп тапшыргандыр.* В.Имамов

7) Әти-әнисе; әтисе яки әнисе булмаган бала; ятим бала. *[Сәлимнең] карточкасында, атасы кем, дигән графада «ялгызак» дигән сүз язылган.* Г.Гобәй. *Сабыйлар йортына тапшырыла гадәттә андый ялгызак балалар...* Г.Гыйльманов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Гаиләсез; буйдак; ирсез яки хатынсыз, тол; ялгыз. *Бәйләнчек йокысызлык чиренең арт санына кызулану-ашыгу гына шартлатып тибә ала, татлы йокыны адәмгә шул гына кайтара, ятакта аунау адәмне йокысызлыкның газаплау кочагына сала, дигән үз кагыйдәсе шулай ашкындырды бугай ялгызак Фарукны.* М.Хуҗин. *Сугышка – ут эченә китеп кайтмый калган асыл егетләрен, улларын һәм ирләрен көтеп зарыккан хатыннарга, кияүгә чыкмыйча калган бүгенге ялгызак кыз-әбиләргә җиңел булгандыр, дисеңме.* Р.Низамиев // Парсыз. *Аны күрүгә, ялгызак аккош, ашыга-ашыга, янына йөзеп килде, килде дә кинәнә-кинәнә түгәрәк ясап йөзә*

*башлады, ә үзе бертуктаусыз саубуллашкандай башын иде.* М.Хәбибуллин

2) Ялгыз; үзе генә булган; аерым урнашкан. *Сугыш та бетте, сазлык киптерәбез дип – тугайларга, чишмәләргә, иген мәйданы арттырабыз, ялгызак агачларны төплибез дип, урманнарга каршы наступлинҗә башланды.* А.Хәлим. *Күктә бакый Җир-ананың сүзсез шаһиты – ялгызак Ай йөзә.* В.Имамов

3) Билгеле бер вакытта, урында үзе генә булган. *Анда-монда гына чыркылдап куйган ялгызак кош тавышына игътибар итеп тә тормыйча, Хәлим, тиз-тиз генә җыенып, тышка чыкты.* Г.Гыйльманов. *Бу авылга очраклы гына килеп чыккан ялгызак кунак идем.* Р.Рахман

4) Чит җирдә, дусларсыз, ярдәмчесез, яклаучысыз һ.б. булган. *Дон Кихот кебек каңгырап читтә йөргән ялгызак татарларны барлап, исемнәрен киләчәк өчен тарихта калдырырга тырышам.* Т.Галиуллин

5) *тар.* Күмәк хуҗалыкка кермәгән; аерым хуҗалык булып калган. *Әмма колхозга керми. Гомерен ялгызак игенче, тегермәнче, тимерче, балта остасы булып үткәрә.* Р.Вәлиев

6) Төп массадан аерылып торган, уникаль, аерым бер; бер өлкәдә, юнәлештә үзе генә, бердәнбер булган. *Ул жанрларны, нигездә, ялгызак язучылар үзләренең иңнәрендә күтәреп баралар.* Р.Миңнуллин. *Бу этапта яңару башлыча идеологик планда бара һәм Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Г.Чокрый һ.б.лар кебек ялгызак энтузиастлар эшчәнлегендә чагыла.* Фәнни Татарстан

7) Бер; аерым бер; ялгыз булып ишетелгән (тавыш тур.). *Тагын халык ялгызак тавыш килгән якка борылып карады.* Ф.Җамалетдинова

8) лингв. Парлы булмаган; кабатланмый торган. *Кем – шул, кайда – шунда, ничек – шулай, ни – шул, кемнең – шуның кебек сүзләр парлы мөнәсәбәтле сүзләр дип, шул, шуның, моның, моңа, шунысы, шуңа күрә һ.б. алмашлыклар ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр дип аталып йөртеләләр.* Ф.Хисамова. *Ялгызак ияртемнәр: гөрс, гөлт; парлы ияртемнәр: ялт-йолт, шак-шок; кабатланып килгән ияртемнәр: дер-дер, кар-кар; өч компонентлы аваз ияртемнәре: ха-ха-ха, хи-хи-хи.* Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе

**3.** *рәв. мәгъ.* Ялгызы гына, үзе генә; аерым гына. *Күкеле сәгатьнең ике як канатында – хуҗаларның ялгызак, парлап, балалары белән төшкән фотосурәтләре.* А.Хәлим. *Аларның бу халәтен Лотфулла абзый белән Мөҗәһирә апа да, күреп, тоеп торып, инде ничәнче ел ялгызак яшәгән кызлары өчен эчтән генә куансалар да, нәрсә кылырга, үзләрен ничек тотарга икәнен белми кыенсынып аптырагannar иде.* Л.Ибраһим-Вәлиди

**ЯЛГЫЗДА́Н-ЯЛГЫЗ** *рәв.* Үзе генә, бөтенләй берүзе; япа-ялгыз. *Житмәсә, уң аягы гипска салынган булганлыктан, йөри дә алмый, төннәр-көннәр буе уйлары белән ялгыздан-ялгыз яшәргә мәҗбүр.* Г.Әпсәләмов. *Ялгыздан-ялгыз калды шул, мескен...* Ә.Хәсәнов

**ЯЛГЫЗЛЫК** *и.* **1.** Ялгыз булу хәле. *Алда юл, алда мәшакатьле төн, алда Зәй, алда ялыктыргыч ялгызлык...* А.Гыйләҗев. *Көне буе үз эчемә бикләнеп йөргәннән соң, бар уйларымны аңа сөйлим: мәгънәсез, караңгы тоелган бу дөньяда ул гына мине аңлый, ул гына мине ялгызлыктан аралый иде.* А.Әхмәтгалиева

**2.** *с. мәгъ. лингв.* Бер төрдән булган предметларның берсенә генә бирелә торган (исем тур.). *«Габдулла Тукай: Шигърият теле» сүзлегенең конкордансында кулланылышы чикләнгән (искергән, диалекталь, алынма һ.б.) сүзләргә, ялгызлык исемнәргә кыскача аңлатма бирелә.* А.Тимергалин. *Күмәклек исемнәр белән аталган ялгызлык исемнәр тәрҗемә ителми: «Берёзка» ансамбле, «Юность» кинотеатры, «Осень» кафесы, «Сирень» одеколоны.* Р.Юсупов

**ЯЛГЫ́З-ЯБАГА** *җый. и.* Ялгыз яшәүче кешеләр, ялгызаклар. *Гайшә инде безнең кебек ялгыз-ябаганың ишеген ачарга теләмәс.* Ф.Бурнаш. *Минем кебек ялгыз-ябаганың ишеген шакучылар азайды.* Кызыл таң

**ЯЛГЫ́З-ЯБАГАЙ** *җый. и. сөйл. к.* **ялгыз-ябага**. *Карт янында үземнең ялгыз-ябагай икәнлегемне беразга онытып торсам да, бу бер кайгысыз яшьләр янында мин үземне тагын беркемгә дә кирәкмәгән, бәхетсез, ялгыз адәм итеп сиздем.* Сөембикә. *Байлыкларын уңгасулга сипкәндә, тиеннәрен санап көн күрүче ялгыз-ябагайны, ярдәмчесез калган карт-корыны, ятим-яртыны, авыругарипне күрерләр, өлеш чыгарырлар – савап алырлар иде.* Безнең гәҗит

**ЯЛГЫ́З-ЯРЫМ** *рәв.* **1.** 1) Ялгыз гына, үзе генә. *Ул, солдатларына җитәкчелек итүне ташлап, ялгыз-ярым котылу ягын карады.* Г.Әпсәләмов. *Аның ише ялгыз-ярым көн иткән картларны күрше авылдагы картлар йортына җыялар җыюын...* А.Хәйретдинова

2) Аерым, үзе генә, башкалардан аерым (урнашу, утыру тур.). *Башка өйләрдән читтә, ялгыз-ярым утырганлыктан, Ихсанбайлар өендә чыккан янгын башка йортларга күчмәгән.* Т.Гарипова

**2.** *с. мәгъ.* Аерым-аерым булган, берән-сәрән. *Юлларда калган ялгыз-ярым вагоннар, паровозлар гына әле һаман да яналар, станция биналарының, пакгаузларының калдыклары да төтенли.* Г.Әпсәләмов. *Ялгыз-ярым агачлар. Ялгыз-ярым йортлар*

**ЯЛГЫ́З-ЯТИМ** *с.* **1.** Әти-әнисе, туганнары булмаган; ятим; үз кешеләре, гаиләсе булмаган. *Шушы батыр хатын, үзе дә ялгыз-ятим булгангамы, Гөлназны үз итә.* И.Нәбиуллина

**2.** *рәв. мәгъ.* Ялгыз килеш, ятим хәлендә, әти-әнисез; гаиләсез, якын кешеләрсез. *Кайгыны ил белән күтәрерсез, кайгы-хәсрәткә, төшенкелеккә бирешеп, балаларның хәстәрен җибәрмә, син ялгыз-ятим калмыйсың, яныңда үсеп җиткән алты яшьлек олы кызым Гөлсерүр кала.* Хезмәт даны

**3.** *и. мәгъ.* Әти-әнисе, туганнары, гаиләсе булмаган кеше. *Ялгыз-ятим кайгылардан арынмас, Мәҗлесләрдә исеме телгә алынмас.* Э.Шәрифуллина. *Бүгенге көндә андый гаиләләрдә 11 меңнән артык бала тәрбияләнә, бу – барлык ялгыз-ятимнәрнең 91 проценты дигән сүз.* Сөембикә

**ЯЛГЫ́З-ЯТИМӘ** *с.* Ялгыз, ятим хатын-кыз. *Рухы тынычлансын дип, Габделбәр ялгыз-ятимә карчык Маһруй әбигә хәер дә биреп карады, тик алай да файдасы тимәде.* Ш.Маннапов. *Ялгыз-ятимә килеш карап үстергән анасының барлыгын да белмәгән, читтә йөргән зимагур бала, дип әйт!* Кызыл таң

**ЯЛГЫШ** *и.* **1.** 1) Язуда, исәпләүдә, эштә һ.б.ш. дөрес булмаган нәрсә, хәл, хәрәкәт; хата. *Син тагын өченче ялгыш ясамакчы буласыңмы?* Н.Фәттах. *Әлеге укучы, үзенең нindider ялгышын күреп, эшли башлаган эшен аркылы-торкылы сызгалаган да дәфтәрен урамга, җилләр иркенә ташлап калдырган.* Г.Сабитов

2) Хата, алдау; дөрес булмаган факт; ялган. *Әмма ул төнне керфек тә какмадым, дисәм дә ялгыш булмас.* В.Нуруллин

**2.** *с. мәгъ.* 1) Дөрес булмаган, хаталы; дөреслеккә туры килми торган. *Ибрай*

*күршеләре турында гел ялгыш фикердә булган икән ләбаса.* Ф.Яруллин. *Солтанъяр абыйның моңа кадәр ялгыш сүз әйткәне юк иде, бу юлы да белми әйтмидер, дип, бу гамәлендә аңа сылтанды.* З.Мурсиев

2) Урынсыз, әйтергә ярамаган (сүз тур.). *Шулчакны Ак әбинең күзләрендә ике бөртек кенә яшь күренде, һәм Гыйлемдар үзенең ниндидер ялгыш сүз әйткәнен аңлады.* А.Тимергалин. *Ялгыш сүз ычкындырмагаем тагын дигәндәй, егет каушап калды.* А.Фәләх

3) Ялгышып эшләнгән; хата белән кылынган, хата җибәрелгән. *Соңгы вакытта бер-бер артлы уңышсыз операцияләр, ялгыш диагнозлар булып алды, янә шул табиблар җитмәве, су буе чиратлар халык арасында ризасызлык тудырды.* З.Мурсиев

4) Яман, начар; яхшы булмаган. *Үзенең ниндидер ялгыш адымга баруын бөтен йөрәге, бөтен күңеле белән сизенсә дә, аякларын тыңлата алмады Гөлия.* Җ.Дәрзаман // Бозык. *Дин берәүне дә ялгыш юлга җибәрми!* Г.Шәйхи

5) Дөрес булмаган; кирәк җиргә алып бармый торган; башка җиргә, башка юнәлешкә алып бара торган (юл тур.). *Бераз хәл кергәч, тагын торып киткән, әмма урманны аркылы чыгып җитә алмаган, адашып, ялгыш юлдан киткән һәм, сазлыкка очрап, шунда юкка чыккан.* Г.Гыйльманов

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Ялгышып, хаталанып. *Яраланган кабан дуңгызын куып, ялгыш бу якка йөзеп чыкканмын.* Аманулла // Алай эшләргә ярамаганын белмичә. *Күрәсең, Мәдинә ханым ялгыш чынаякны түккән иде.* Г.Әпсәләмов

2) Хата белән; дөреслеккә туры китермичә; тиеш яки кирәк булганча. *Кызганычка каршы, «Татар энциклопедия сүзлеге»ндә басым ялгыш күрсәтелгән булып чыкты (соңгы иҗеккә төшкән итеп бирелә).* А.Тимергалин. *«Берәр кәгазем ялгыш язылды микәнни?» – дигән уйлар буталды аның авырайган, ачыгудан чыңлап кысылып авырта башлаган башында.* Д.Каюмова

3) Башкача, дөрес булмаганча; чынлыкта булганнан үзгәрәк итеп (күрү, ишетү һ.б. тур.). *Ул, ялгыш ишетмәдемме, бүтән бер Сафинаны атамадыларммы дип, иптәшләренә дә карап алды.* Г.Әпсәләмов. *Әллә күзенә ялгыш күренәме?* Г.Әдһәмова

4) Игътибарсызлык белән. *Бер тапкыр ул җиңе белән ялгыш мич авызындагы коймак табагын да эләктереп төшерде.* Ф.Җамалетдинова

5) Очраклы рәвештә, алдан белмичә. *Ул, юка бозга ялгыш килеп кереп, бата башлаган кеше кыяфәтендә иде.* Х.Камалов

◊ **Ялгыш юлга кертү** 1) Хата җибәрергә, хаталанырга, ялгышырга юл кую, этәргеч булу, мәҗбүр итү. *Адәм – ялгыш юлга керткән, Акылыннан яздырган!* И.Юзеев. *– Әйе, җиңел генә түгел... – дип уйланып җавап бирде Камалов һәм шуның белән әңгәмәдәшен ялгыш юлга кертеп җибәрде.* Р.Мирхәйдәров; 2) Бозык юлга бастыру. *Пәри – шул ук җен ләбаса инде ул, адәм баласын аздыра, ялгыш юлга кертә.* М.Әмирханов. **Ялгыш юлга керү** 1) Дөрес гамәлләр кылмау; дөрес юлдан бармау, ялган кыйммәтләр белән яшәү. *Кешелек ялгыш юлга кереп китте, һәм ул моның өчен җавап бирәчәк...* Ф.Бәйрәмова. *Илеңнең, халкыңның шул рәвешле адашып, ялгыш юлга кереп баруына битараф кала алмыйсың син!* Р.Мөхәммәдиев; 2) Бозык юлга басу. *Ирләр белән чуалып, ялгыш юлга кереп киткән кызлар да аз булмады.* Ф.Хуҗин. *Балаларның ялгыш юлга кереп китүе бик тиз бит ул.* С.Ибраһимова. **Ялгыш юлга (юлдан) китү** Ризыкның тын юлына китүе. *Аракысы ялгыш юлдан киттеме, башка сәбәпме – Җәмил чәчәде, буылып-буылып ютәлләргә керешге.* Н.Әхмәдиев. *Шулай дип акыруы булды, хәлвә ялгыш юлга китә язып, хуҗа йөткерергә, ыһы-ыһы килеп гыжылдарга, төкеренергә тотынды.* З.Мәхмүди

**ЯЛГЫШЛЫК** *и.* 1) Ялгыш хәл, хата. *Мәликә апаның безгә – Каусәрия энеләренә каныгуын, бәлки, шул ялгышлык аңлата торгандыр?* В.Юныс. *Галәмдә ниндидер ялгышлык: бу соңга калган көзге яшен күпләрне хафага салды.* Д.Каюмова

2) Ялгышу очрагы. *Кызмыйча гына уйлап кара: берәр җирдә хаксызлык, ялгышлык эшләп ташламадыңмы?* А.Гыйләҗев. *Киресенчә, алар синең ялгышлык җибәрүеңне көтеп йөриләр.* В.Нуруллин

◊ **Ялгышлык белән** 1) Ялгышып, хаталанып. *Мафия кешеләре аны ялгышлык белән урлаган. Кем беләндер бутаганнар.* А.Хәсәнов. *Исмәгыйльне ялгышлык белән зинданга салган булганнар, гаепле кешене тотканнар, диярбез.* Ф.Яхин; 2) Уйламыйча, очраклы рәвештә; начар уй, усаллык белән түгел. *Тикшергәндә, ялгышлык белән, француз телен әз-мәз беләм, дип ычкындырганмын...* Д.Салихов. *Ялгышлык белән, ачудан гына әйтелгән сүз булса да, Расих, үзе уенча, ирлеген итте: шул кичтә үк, чемоданнарын төяп, иптәшләре янына тулай торакка күченде.* Р.Рахман

**ЯЛГЫШЛЫ́К ИТҮ** *ф.* Ялгышу, хаталану. *Кичә без бу дуамалга тавыш чыгарып бәйләнүебез белән зур ялгышлык иттек.* Г.Камал. *Аларда үскәнемне язмыйча, мин бик зур ялгышлык иткәнмен.* Г.Кутуй

**ЯЛГЫШЛЫ́К КЫЛУ** *ф. к.* **ялгышлык итү**. *Иң авыры – хәзер минем үземә дә ниндидер бик зур гаебем бардыр, тормышта ниндидер төзәтеп булмаслык зур ялгышлык кылганмындыр кебек тоела башлады.* Р.Вәлиев

**ЯЛГЫШУ** *ф.* 1) Ялгышлык җибәрү, хаталану. *Ялгышкан бит ул, һәр адәм баласы кебек ялгышкан...* Г.Гыйльманов. *Кайда ялгышты соң Рәхимҗан, кайчан хаталанды?* А.Әхмәтгалиева // Дөрес эшләмәү. *Тик менә авылыбыз кызына өйләнми бераз ялгышты бугай егетебез.* Г.Галиева

2) Берәр кеше, берәр нәрсә турында дөреслеккә туры килми торган, ялгыш фикердә булу; дөрес уйламау, дөрес фикер йөртмәү. *Шактый ук күңелсез, бик гомуми сөйләшү булыр дип уйлаган идем, әмма ялгышканмын.* М.Хәсәнов. *Бәхет тигезлектә генә, дип ялгышасың.* Р.Рахман

3) Башкача ишетү; ялгыш ишетү, күрү, кабул итү. *Җир астында, табигый хәл: Колакларың ялгышкан...* И.Юзеев. *Аның колаклары ялгышмаган икән, сорнай тавышы чыннан да ишетелә иде.* Р.Батулла

4) *күч.* Саташу. *Аның зиһене ялгышкан иде...* Г.Гыйльманов // Акылдан язу, юләрләнү, диванага әйләнү. *Житмәсә, күзләре ачык, ялгышкан кешенеке шикелле мәгънәсез карамыйлар.* З.Мурсиев

**Ялгыша бару** Вакыт үткән саен күбрәк ялгышу. *Шуңа күрәме, малай ялгышын төзәтү урынына ныграк ялгыша бара.* С.Баттал

**Ялгыша башлау** Ялгышырга тотыну; ялгышу билгеләре сизелү, күренү. *Бала куркудан чирләп китсә, ялгыша башласа, зиһенен буташтырса, шушы йоланы башкаралар.* Г.Гыйльманов. *Алар, авыр кайгыдан бу ханым бераз ялгыша башлаган, дип уйлап, күзенә туры*

*карамадылар, дорфа эндәшмәделәр, эзләнү турында кабул ителгән карар алты ай үтүгә көчен югалта, хәзер без бу эшкә яңадан тотына алмыйбыз, дип аңлаттылар.* З.Мурсиев

**Ялгыша бирү** Һаман да ялгышу. *Берсе артыннан икенчесе, дигәндәй, һаман да ялгыша бирдем.* Ф.Яхин

**Ялгыша төшү** Бераз ялгышу; тагы да ялгышу. *Әмма мәкалә авторы ялгыша төшә.* И.Вәлиулла

**Ялгышып җибәрү** Кинәт ялгышу; бераз ялгышу. *Җырчы ялгышып җибәрсә, тамашачылар елмая гына, ә диктор ялгышса, аңа эштән куылу кебек җитди чаралар яный.* Безнең гәҗит

**Ялгышып йөрү** Гел ялгышу; озак вакыт дәвамында ялгышу. *Минем дә, замана шаукымына ияреп, адашып, ялгышып йөргән чаклар булды.* Ватаным Татарстан. *Моңарчы черек бәрәңге коймагын иң тәмлегә санап ялгышып йөргәнбез, аңардан да тәмле, аңардан да ашап туйгысыз ашамлыклар да бар икән дөньяда!* Кызыл таң

**Ялгышып китү** Кисәк ялгышу; билгеле моменттан ялгыша башлау. *Тәмам ялгышып китмәс өчен, мин үзем дә әбекәй белән сөйләшмим.* Г.Гыйльманов. *Элегрәк миңа, ялгышып китеп, Наилә дип эндәшкәләде.* Р.Зарипов

**Ялгышып кую** Көтмәгәндә ялгышу. *Борынгы ташларда кемнең исеме язылган, томанлы заманнарда ата-бабаларыбыз кемнәр булган, дип уйлана торгач, әллә акылы ялгышып куйдымы.* З.Мурсиев. *Ярый әле баш бухгалтер бик үткен күзле, югыйсә, гел бер нәрсәне уйлый торгач, хисабыңда да ялгышып куюың бар.* Р.Рахман

**Ялгышып тору** Әледән-әле ялгышу. *Шуңа күрә автобус йөртүчеләр еш кына ялгышып торалар.* М.Юныс. *Алай дисәң, табиблар да гел ялгышып тора.* Р.Зәйдулла

**ЯЛДА́У** *ф.* **1.** диал. 1) Атларны, терлекне су кертү, коендыру. *Анамнан туганлы бирле ат ялдаганым юк иде.* Шәҗәрәи төрек

2) Елга, сулык аркылы күперсез, судан кичү; атны судан алып бару. *Элекке заманнарда күчмән төркиләр тирән елгаларны башлыча ялдап кичкәннәр; хатыннар һәм бала-чагалар күпергә утырып кичкән.* Р.Әхмәтьянов

**2.** *и. мәгъ.* Атларны су кертү, коендыру урыны. --- *йалда-у фигыленнән исемләшкән һәм «атны су кертерлек урын» мәгънәсен алган.* Р.Әхмәтьянов

**ЯЛДЫ** *и. диал.* 1) Өйнең яши торган өлеше белән тышкы ишеге арасындагы ягып җылытылмый торган корылма; өйалды. *Аннан соң тагын йортның арткы түренә тоташтырып салынган һәм без балалар бик ярата торган зур тәрәзәле ялдысы бар иде. Ялды йортның үзеннән шактый соңрак салынган иде булса кирәк.* Р.Даутов

2) Мунча һ.б.ш. корылмаларның төп өлеше белән тышкы ишеге арасындагы өлеше. *Без улым белән ул төнне мунча ялдындагы ике кешелек диван-караватта йокладык.* М.Мәһдиев

**ЯЛЕ** *ы. к.* **я** II (*1, 2 мәгъ.*). *Габдерәшит карт, дилбегәсен кагып: – Яле, малкай, юыртыйк әле! – дип, гомер куаламаган атын ашыктырды.* А.Тимергалин. *– Яле, бир әле, – ди Борһан бабай, тимер чыбыкның бер очын авызына каба-каба.* Аманулла

**Я́Л ИТҮ** *ф.* 1) Нинди дә булса эш башкарудан вакытлыча туктап тору; эшне, хәрәкәтне туктатып тору; көч туплау; тын алу; хәл җыю. *– Хәлем юк, бусагагызда гына утырып ял итимче, тышта эссе, – диде хатын, чак ишетелерлек итеп.* Р.Батулла. *Бераз гына ял итеп алыйм дип, караватыма сузылып яттым.* М.Вәлиев

2) Башның, аяк-кулларның һ.б. арыганлыгын бетерү өчен, шөгыль алыштыру; билгеле бер эш-хәрәкәт туктатып торып, башка нәрсә белән шөгыльләнеп алу. *Галимә, баянда оста уйнаучы кыз буларак, тәнәфес вакыты җитте исә, укучыларны биетеп, ял иттертеп ала.* Ф.Яхин. *Бирегә, укудан ял итеп – йөгереп, сикереп алу өчен, өч спорт залы көне буена ачык торачак, футбол уйнау өчен аерым кыр, ясалма түшәлгән йөгерү юллары, зур бассейн, тир, ике актлар залы, хореография залы да бар.* А.Әпсәләмова

3) Эшкә, укуга һ.б. бармау. *Өйләдә бер сәгатьлек тәнәфес ясала, җомга көнне ял ителә.* Т.Әйди. *Унбиш көн эшләп кайта да унбиш көн Вәсиләсе янында ял итә.* Ф.Баттал

4) Билгеле бер эштән соң яки буш вакытларда үзе теләгән нәрсә белән шөгыльләнү; вакытны үзе теләгәнчә уздыру. *Кичләрен ял иткәндә, син пианино янына килеп утырасың да җырлыйсың.* М.Мәһдиев

5) Рәхәт итеп вакыт үткәрү өчен, саф һавада яисә төрле биналарда һ.б. ясалган, билгеләнгән махсус урыннарда булу; шундый урыннарда йөрү. *Малайлар әтиләре белән паркта ял итеп кайтты.* Р.Вәлиев. *Халык паркларда, сәүдә үзәкләрендә ял итәргә өйрәнеп бетте.* Идел

6) Диңгез буена, чит илләргә, санаторийларга һ.б. җанга-тәнгә рәхәтлек, ләззәт бирә торган урыннарга бару; шундый урыннарда үзе теләгәнчә күңелле итеп вакыт уздыру. *Аның хезмәт хакын долларлар белән санап, Канар утрауларында ял итәсе, зиннәтле коттеджларда яшисе, тәмледән-тәмлене ашыйсы – кыскасы, типтереп яшисе килә.* Ә.Рәшит. *Эшлисең, эшлисең, ә ял итәрлек акча юк.* Н.Алан

7) *күч.* Туктап тору; эшләмәү; кулланылмау. *Илаһи бер мизгел: туплар атмый, Кылыч та ял итә кынында.* Ф.Мортазин. *Кызыл погонлы кителе бүген аның гардеробында ял итә.* Т.Нәҗмиев

8) *күч.* Тынычлыкта калу. *Балта чапканчы, түмәр ял итә.* Х.Камалов. *Кайчак колак та ял итәргә мохтаҗ.* Р.Батулла

9) *күч.* Ләззәтләнү; рәхәтлек алу (җан, күңел тур.). *Җан ял итсен өчен, миңа шома асфальттан чирәмле җиргә чыгу кирәк.* Ш.Галиев. *Хәзер дә өйдә үзебез генә булганда, акрын гына магнитофон куябыз да, күңел ял итә.* И.Фәйзрахманов

**Я́Л ЙОРТЫ** *и.* Кешеләр ял итсен, көч тупласын өчен, табигатьнең матур урынында яки курорт зонасында урнашкан ял һәм туризм учреждениесе. *Эшләгән урыныңда җәйге ялга чыккач, ял йортларына юлламалар бирделәр, әле барырга да мәҗбүр иттеләр.* Н.Галиев. *Абзый күңеле булганчы җырлап бетергәнне көтте дә, иплә кенә сүз кушты Билал: – Бабай, әллә син дә ял йортына барасыңмы?* М.Вәли-Барҗылы

**ЯЛКА́У** *с.* **1.** 1) Эш яратмый торган, иренчәк. *Ялкау малай исә, яр буенда кырын яткан килеш, авыз эченнән генә һаман мыгырдана икән: – Ямаганда, энә белән бармакка кадасам?* Әкият. *Ялкау кеше, ничек эшләмәскә, дип план корып ята да берәр хикмәт уйлап чыгара.* Т.Миңнуллин

2) *күч.* Әкрен хәрәкәтләнә торган. *Ләкин шулчак тукталышка, озын мөгезләрен тырпайтып, бер ялкау троллейбус килеп туктады, һәм егетебезне үз куенына тартып алып, ыңгыраша-ыңгыраша күздән югалды.* Р.Габделхакова

3) *күч.* Әкрен, салмак, сүлпән; артык тыныч. *Бары тик утыргыч янындагы, хуҗасы янында казынып яткан бер*

*бульдог кына ялкау күз карашы белән Җәмилне озатып калды.* Н.Әхмәдиев. *Алар үзләре күренмиләр, бары шул йокымсыраган ялкау тавышлары гына ишетелә иде.* Н.Фәттах

**2.** *и. мәгъ.* Эш яратмый торган кеше. *Сәләтле эшли, булдыра, ә ялкау берни эшләми, буталып тик йөри.* Х.Камалов. *Уңган бүгенгесен бүгендә бетерә, ялкау бүгенгесен иртәгәгә калдыра, кайберсе иртәгесен киләчәккә аудара.* Г.Хөсәенов

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) Иренеп кенә, ялкауланып. *Зөһрә ялкау гына урыныннан торды.* Ф.Яруллин. *Иртәнге йокыны бүлдегез дигәндәй, кайдадыр ялкау гына эт өреп куйды.* Ф.Садриев

2) *күч.* Теләр-теләмәс кенә, артык салмак, әкрен итеп. *– Булмый бит, абый! – диде Зөфәр, ялкау гына елмаеп.* Ә.Еники. *– Саттык шунда, – диде ул, ялкау гына.* Н.Фәттах

3) *күч.* Әкрен, салмак хәрәкәтләнеп (агым, җил, хәрәкәт һ.б. тур.). *Тирә-як тып-тын, шылт иткән тавыш юк, тик түбәннән диңгез дулкыннарының ярга ялкау гына килеп кагылулары ишетелә.* Ә.Еники. *Ялкау гына искән җил ат караучыларның эзен кар белән тигезләде.* Н.Әхмәдиев

4) *күч.* Ишетелер-ишетелмәс, сүрән тавыш белән. *Тынлык, шылт иткән тавыш юк, тик кипкән үлән арасында ялгыз чикерткә ялкау гына чырылдый.* Ә.Еники. *Уйлар чабышын өзеп, ялкау гына шыгырдап, ишек ачылды.* А.Вергазов

◊ **Ялкауга ял килү** Эшләмәс өчен, ялкау кешегә гел сылтау, сәбәп табылып тору. *Яңа күршеләр килгәнен, үзләренең кунакка чакырулы икәнен белгәч: – Һе, ялкауга ял килгән, сиңа аш пешермәскә җай чыккан икән, – дип кеткелдәде.* М.Маликова. **Ялкауга ял табылу** *к.* **ялкауга ял килү**. *Ялкауга ял табылып кына тора.* Э.Яһүдин. **Ялкау сату** Ялкаулану. *Бу үле туган бәндәнең акрын кыймылдавына, күрәләтә ялкау сатуына, мөгаен, мишәр егетенең тәмам ачуы чыккандыр.* К.Миңлебаев

**ЯЛКАУЛАНДЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **ялкаулану**. *Эссе һава кешене бик ялкауландыра икән, бер дә урыннан кузгаласы килми икән.* Г.Камал. *Имеш, ул, ягъни Сафа Гәрәй хан, яу йөрмичә, гаскәрне артык симертә, атларны ялкауландыра, сугыш һөнәре онытыла бара.* Р.Батулла

2) *з.-сыз. к.* **ялкаулану**. *Бусы болай гына, ялкауландырып кына ауната.* А.Гыйләҗев

**Ялкауландыра бару** Торган саен ныграк ялкауландыру. *Хәрәкәтсезлек ялкауландыра бара*

**Ялкауландыра башлау** Ялкауландырырга тотыну. *Айлар буе ял итү ялкауландыра башлады*

**Ялкауландырып бетерү** Тәмам ялкауландыру. *Тәки бозып, ялкауландырып бетергән сезне социализм.* Ф.Баттал. *Иртәдән алып кичкә кадәр диванда китап укып яту да, көннәр* буе *интернет салоннарда утыру да дөрес түгел, чөнки, хәрәкәттә бәрәкәт, дигәндәй, мускулларыгызны ялкауландырып бетерәсез.* Шәһри Казан

**ЯЛКАУЛАНУ** *ф.* 1) Ялкаулыкка бирелү; ялкауга әйләнү. *Без илтифат итмибез, өйрәнгән тормышыбызга үзгәреш кертәсебез килми, ялкауланабыз, алда әле барысы да дип, үзүзебезне юатабыз.* К.Кара. *Барыбыз да шулай ялкаулансак, Кая барып терәлер бу дөнья?!* М.Кәбиров

2) *күч.* Үз функциясен элеккегә караганда начаррак башкару; әкренрәк, начаррак эшләү. *Кояш югары менгән саен, калкавыч ялкауланды һәм, баталкалка арыпмы, йокыга китте.* М.Хуҗин. *Ялкауланган баш мие җавап эвәләгән арада, Диана аны кызларга илтеп тә тапшырды.* Н.Гыйматдинова

**Ялкаулана бару** Торган саен ныграк ялкаулану. *Артык ирек куйган, аның көннән-көн ялкаулана баруын күрмәгән.* Л.Ихсанова. *Эшсезлектән елдан-ел ялкаулана барган авыл ирләрен җыеп, нәрсә төзергә кирәклеген аңлаткач, мужикларның күбесе, тәмәкесен гөжләтә-гөжләтә көлеп, акрын гына атлап кире кайтып китте.* Г.Мирһади

**Ялкаулана башлау** Ялкаулану билгеләре сизелү. *Мин ялкаулана башладым булса кирәк.* Г.Бәширов. *Киреләнеп, аз гына ялкаулана башласам, гел шул сүзләрне кабатлый, аннары мин ирексездән китаплар укырга мәҗбүр була идем.* К.Тимбикова

**Ялкаулана төшү** Бераз ялкаулану; тагы да ялкаулану. *Бәлки, бу – минем язуга соңгы елларда бераз ялкаулана төшүемнәндер?* Ш.Бикчурин. *– Халыкның ялкаулана төшүе борчуга сала, – ди рәис.* Кызыл таң

**Ялкауланып бетү** Тәмам ялкаулану; бик нык ялкаулану. *Шуңа алар ялкауланып беттеләр, үзләренә ризык табарга да иренәләр.* Р.Габделхакова

**Ялкауланып йөрү** Гел ялкаулану; озак вакыт дәвамында ялкаулану. *Юкка гына ялкауланып йөрдем, Күрәм, малай, башым җуярлар...* Һ.Такташ. *Башта ялкауланып йөргән идем, аннан* ныклап әзерләнә башладым. Ялкын

**Ялкауланып җитү** Тәмам ялкаулану. *Ялкауланып җиттегез, «алма пеш, авызга төш» дип кенә ятасыз инде.* Р.Вәлиева

**Ялкауланып калу** Берәр нинди сәбәптән, тәэсирдән, вакыйгадан соң ялкаулану; ялкауга әйләнү. *Җылы кышка ышанганмы, Ялкауланып калганмы – Әллә инде бөтенләйгә Сайлаганнар каланы?* Г.Әпсәләмов

**Ялкауланып китү** Соңгы арада ялкаулану. *Дошманнарга рәхмәт әле – Котырталар, Ялкауланып китсәм, эшкә Утырталар.* Ш.Галиев. *Соңгы вакытларны ни өчендер ялкауланып киттем, көндәлек тә язылмый башлады.* Ш.Алпар

**Ялкауланып кую** Сирәк кенә, кинәт, көтмәгәндә ялкаулану. *Кышка шикәрне күбрәк калдырсаң, икенче елга кортларың ялкауланып куярга да мөмкин.* Ватаным Татарстан

**Ялкауланып тору** Озак вакыт ялкаулану; һаман ялкаулану; әле, хәзер ялкаулану. Т*еләгән кешегә әллә никадәрле мөмкинлек бар, эшлә генә, ялкауланып торма.* М.Миначев. *Хатыны әйтүенчә, бервакытта да зарланмый, ялкауланып тормый, эх дигәнче, әллә нинди ерак өлкәләрне әйләнеп кайта.* Безнең гәҗит

**Ялкауланып утыру** *сөйл. к.* **ялкауланып тору**. *Ялым ике ай, өлгерермен әле, дип ялкауланып утыра торганнардан түгел ул – әз генә вакыты килеп чыктымы, өй эшенә чума.* Җ.Юныс

**Ялкауланып яту** *сөйл. к.* **ялкауланып тору**. *Гомердә булмаганны, ялкауланып ятма!* В.Нуруллин. *Ялкауланып ятсаң, кич клубка чыгармавы да бар.* Г.Әдһәмова

**ЯЛКАУЛА́РЧА** *рәв.* **1.** Ялкауланып; ялкауларга хас булганча; ялкаулар кебек. *Руслан, кесәсеннән наушник алып колагына кия-кия, ялкауларча иңәлеп, миңа карады.* А.Әхмәтгалиева

**2.** *с. мәгъ. сөйл.* Гадиләштереп; гадирәк итеп эшләнә торган; гади. *Газон ясау эшендә ялкауларча алым исә мондый: бакча участогы җирен ничек бар шулай калдырабыз.* Кәеф ничек? *Ялкауларча тулма пешерү өчен, кәбестә, суган, кишер, помидор, сыер ите фаршы, үрдәк ите, дөге, тоз, борыч кирәк.* Сөембикә

**ЯЛКАУЛАШУ** *ф. диал. к.* **ялкаулану**. *Аның кулы, көн буе Хәмиткә эш*

*эшли торган, Хәмитнең бөтен теләгєн, уен һич карышмаенча кыла торган кулы, хәзер әллә кемнең рөхсәтен алмаенча хәрәкәтләнә алмыймы, ялкаулашкан гынамы?* Г.Исхакый. *Шәһәрдә яшәүче күп әти-әниләр ялкаулашты: башлангыч сыйныфта укучы балалары белән өй эшен эшләргә дә репетитор яллый.* Кызыл таң

**Ялкаулаша башлау** Ялкаулашу билгеләре сизелү. *Психологлар фикеренчә, шушы бик тә уңайлы технологияләр ярдәмендә балалар үзлегеннән уйларга, күзалларга ялкаулаша башлады хәтта, чөнки «тылсымлы интернет»ка керсә, шундук кирәкле мәгълүмат пәйда була.* Кызыл таң

**ЯЛКАУЛЫК** *и.* Ялкау булу сыйфаты, ялкаулану гадәте. *Безнең халык борынгыдан килгән гадәтенә тугры: ашсуны мул әзерли, үзе әзерли, ул иренми, аңарда ялкаулык юк.* Б.Рәхимова. *Өендә ялкаулык күрмәсә, бала ялкау булмый...* М.Мирза

**Я́Л КӨНЕ и.** 1) Укудан, хезмәттән азат ителгән көн (күпчелек кешеләр өчен шимбә-якшәмбе һәм бәйрәм көннәре); *киресе:* **эш көне**. *Ял көне – якшәмбе булса да, халык күп иде, көчхәл белән этелә-кысыла керде.* Р.Кәрами. *Шимбә көнендә ничек дип төш күрсәң, өнеңдә шулар булыр, чөнки бу көн – ял көне, бәндәләр җиңеләеп ял итәргә тиешләр.* Ф.Яхин

2) Эшкә бармый торган, эштән азат ителгән көн (эш графигы һ.б.ш. рәсми нигездә атнаның теләсә кайсы көненә туры килергә мөмкин). *Ахирәте Саниянең бүген ял көне икән, ә Галия, чынлап та, аңа яшәргә күчкән, имеш.* К.Кара. *Ләкин бүген ире Ришатның ял көне, бакчадан баланы ул алып кайта ала.* Д.Булатова

3) Эшләми торган; хезмәт күрсәтми торган көн. *Икенче көнне, ни кызганыч, банкта техник ял көне булып чыкты.* Р.Рахман. *Дүшәмбе базарның ял көне санала икән бит, белмәгәнбез шуны.* Идел

**ЯЛКУ** *ф. диал. к.* **ялыгу**. *Кайнар йөрәк хисләрен тылсымлы юллар итеп тезәргә яратылган шигъри каләм асфальт астына түшәлә торган чуерташ кебек гел бертөсле сүзләрне, саннарны язудан ялкый, тыпырчына.* М.Маликова. *Бары тик «Ә аңа минем белән болай тору уңайсыз түгелме икән, күңелсезлектән ялкып, өйгә кереп китмәсме икән?» дигән шик кенә нәрсәдер әйтергә этәрде.* М.Кәбиров

**Ялкып бетү** Тәмам ялку, бик нык ялку. *Ята-ята ялкып бетте – Бу нинди яман гадәт.* З.Мурсиев. *Гел бер үк сүзләрне тукып, әни үзе дә ялкып бетмәде микәнни соң инде?..* А.Әхмәтгалиева

**Ялкып китү** Кинәт ялку; ялкыган хәлгә килү. *Бик тә эштән яки хатыныннан ялкып китсә, Мәсәлим күз уңыннан югала да куя.* Д.Бүләков. *Көн дә бераз капкалап тормасаң – бу хәтле ялдан ялкып китүең дә бар.* Кызыл таң

**ЯЛКЫЛДА́У** *ф.* 1) Яктылык чәчеп, нурланып ялтырау, җемелдәү. *Менә караңгыда... Ут ялкылдый, Туплар шартлый, Ярлар ишелә...* М.Җәлил. *Ялкылдавы зәһәр... Әллә янгын Чорнап алган каен урманын?* И.Сабиров. *Яшен ялкылдый*

2) *күч.* Ниндидер сыйфаты, үзенчәлеге белән аерылып тору. *Кайчандыр эчендәге тулылык, байлыктан ялкылдап тора торган бу пулатның тышкы күренеше үк кайчандыр чиста вә бөтенлектән нурланып торганлыгын [күрсәтә].* Ф.Әмирхан

**Ялкылдап китү** Кисәк ялкылдау. *Ут ялкылдап китте*

**Ялкылдап кую** Кинәт, көтмәгәндә ялкылдау; бер тапкыр ялкылдау. *Яшен ялкылдап кую*

**Ялкылдап тору** Һәрвакыт ялкылдау; әле, хәзер ялкылдау. *Ялкылдап һәм янып тора Өй кәрнизе бизәге.* Х.Мөдәррисова. *Менә Иреге, шәп-шәп кенә атлап подъезддан килеп чыкты да, ялкылдап торган «Ленд Крузер»ына кереп утырды.* Сөембикә

**Ялкылдый бару** Торган саен ныграк ялкылдау. *Сөрткән саен кашыклар ялкылдый бара*

**Ялкылдый башлау** Ялкылдарга тотыну. *Ут ялкылдый башлады*

**ЯЛКЫЛДЫК** *и.* **1.** Ялкылдый торган әйбер. *Олы урман, Кече урман, Ялкылдык, Мышкылдык, Кабык абзар ---.* Н.Исәнбәт

**2.** *с. мәгъ.* Ялкылдап торган. *Ялкылдык күлмәк*

**ЯЛКЫН** *и.* **1.** 1) Яна торган әйбер өстендә күтәрелгән ут телләре. *Корысары өстәгәч, ялкын тагын да югарырак үрли, ут телләре көчәйгән саен, тирә-як караңгырак булып күренә.* Г.Гомәр. *Кызгылт ялкын чак кына һава хәрәкәтеннән дә менә сүнәм, менә сүнәм дип тетрәнеп китә ---.* А.Тимергалин

2) *күч.* Нинди дә булса көчле хис. *Эчемдәге ялкын, ургылып, тышка бәреп чыкты.* В.Нуриев. *Йөрәгендә кузгалган шушы ялкын ныграк калка барган саен, Миңнеханны, икенче яклап, әйтерсең лә көнләшү, әрнү хисе дә талый башлады.* В.Имамов

3) *күч.* Энергияле, җитез, өлгер, яшьнәп торган кеше. *Унҗидедә идек, ялкын идек, Матур идек, гөлләр шикелле.* Җыр. *Без булдыра идек яшь чагында, Ялкын иде безнең иптәшләр.* Г.Афзал

4) *күч.* Күтәренке рух, дәрт; илһам. *Бергә-бергә шулай эшләп йөргәндә, Зарифаттигә янә дәрт, ялкын кайтты.* Н.Акмал. *Аны тирәләп алган көчле энергия кешеләргә эшләргә ялкын, дәрт бирә, үзенең артыннан әйди.* Г.Мирһади

**2.** *с. мәгъ.* 1) Кайнар. *Сулавы кыен, уйлавы кыен: Сулышының – ялкын, йөрәгенең салкын чагы.* Г.Гыйльманов. *Ай – салкын, Кояш – ялкын, алар ничек кавышсын инде, ут белән су кушылганын кем күргән, кыскасы, боларның берберсенә якын килүләре булган, Айга ут капкан, чатыр-чытыр килеп, очкыннар чәчрәтеп яна башлаган.* З.Мурсиев

2) *күч.* Дәрт белән тулы, дәртле, ялкынлы, ярсу; тирән тойгылы, хискә бай. *Ник, үзең язгансың бит. Агыйдел кызларының йөрәге ялкын икән, дип.* И.Салахов. *Куллары алтын, йөрәге ялкын, дигәндәй.* Г.Гыйльманов

3) *күч.* Елгыр, үткен, дәрте ташып торган; өлгер, җитез. *Көз көне кырларны шаулаткан Ялкын кыз турында бу җырым.* К.Булатова

◊ **Ялкын кабу** 1) Яна башлау; ут кабу. *Яшен бәрде җирнең күкрәгенә, Ялкын капты черек урманга.* М.Шиһапов; 2) Көчле хис-кичерешләр тәэсирендә йөз, тән кызару, кайнарлану, яну. *Кызның яңакларына ялкын капты, күзләре усалланып елтырый башлады.* Г.Әпсәләмов. **Ялкын кабыну** Көчле хисләр уяну; гашыйк булу, ярату. *Йөрәгендә яңа дәрт, яңа ялкын кабынгач та, Ида искесен исенә дә кертеп карамады.* Н.Фәттах. *Сине күрү белән минем йөрәгемдә Сүрелмәслек ялкын кабынды.* Р.Зарипов. **Ялкын чәчү** 1) Нурланып, балкып, үзенә тартып тору. *Ялкын чәчкән ягымлы серле күзле беренче мәхәббәтен эзләде Таир.* А.Нәҗми; 2) Хисләнеп, ялкынланып, үтемле итеп сөйләү. *Трибунада ялкын чәчми, Астыртын, юаш инде.* Г.Афзал

**ЯЛКЫНЛАНДЫРУ** *ф. йөкл. юн. к.* **ялкынлану**. *Бу исә аның бунтарь аңын тагын да ялкынландыра.* Г.Мөхәммәтшин. *Озын сүзнең кыскасы шул: йөрәкләрдәге дуслык утын тагын да*

*көчлерәк ялкынландырырга ныклап ярдәм итә әлеге ихлас очрашулар.* Ш.Мостафин

**Ялкынландырып җибәрү** Бераз ялкынландыру. *Егетләрнең йөрәген яндырырга, нәфесләрен тагын да ныграк кымҗыртырга, өмет чаткыларын дөрләтеп, ялкынландырып җибәрергә тырышып, кызлар өзелергә торган нечкә билләрен бөгелдереп-сыгылдырып, аркаларына сузылып яткан калын, нәфис толымнарын чайкалдырып, чулпыларын чыңлатып алырга да онытмыйлар.* С.Поварисов

**Ялкынландырып тору** Гел, озак вакыт ялкынландыру. *Юллары да кисешмәде, сукмаклар очраштырмады аларны, ә күңелдә пыскып янган ут көчәйде генә: әйтерсең әйтелмәгән, ачылмаган сер булып калган мәхәббәт кызның йөрәген туктаусыз көйдереп-яндырып, ялкынландырып тора иде.* Туган як

**ЯЛКЫНЛАНУ** *ф.* 1) Ялкын белән яну, ялкын чыгару. *Шәриф абзый хайваннар янына чыгып киткән, ахры, Мәхүп әби, берүзе генә мәш килеп, ялкынланган мич каршында азаплана.* А.Алиш. *Ялкынлана-ялкынлана күтәрелде күккә учак.* Г.Корбанова

2) Нурлану, нур чәчү. *Бераз вакыттан соң күктә Айның тынычланган илаһи төсе ялкынланган Зөһрә йолдыз яктылыгына кушыла.* А.Нәҗми. *Зәңгәр чәчәкләр өстеннән йөгертелгән алтынсу җепләр ай нурларында гүя ут сорап ялкынланалар иде.* Безнең гәҗит

3) *шигъ.* Нинди дә булса хис белән яну, дәртләнү. *Хәзер әйтерсең аның мәхәббәте тирәнәйде, ныграк ялкынланды.* Г.Ибраһимов. *Янды йөрәк, янды, дөрләп ялкынланды...* М.Мирза

4) *күч.* Көчле хисне, дәртлелекне белдереп, чагылдырып тору; нурлану. *Ул күзләр Илсөя килеп керү белән шулкадәр җанлана, ялкынланалар, әйтерсең әйбәтләп шомартылган алмаз бөртегенә төрле яктан нур төшерәләр.* Ф.Яруллин. *Эш сөйсәгез, кешеләрне яратсагыз, тирә-юнегездәге матурлыкны күрә белсәгез, йөзегез нурланыр, күзегез ялкынланыр.* Сабантуй

**Ялкынлана бару** Торган саен ныграк ялкынлану. *Җыр күтәрелә, Мөкәррәмә апаның күзләре ялкынлана бара, безнең дә ачыккан, туңган тәннәребез җылынып киткәндәй була.* М.Мәһдиев

**Ялкынлана башлау** Ялкынланырга тотыну. *Машинада булган өч хезмәткәр тиз арада янгынны сүндерергә керешәләр һәм ялкынлана башлаган утны басалар.* Шәһри Казан

**Ялкынлана төшү** Беркадәр ялкынлану; тагы да ялкынлану. – *Бүредән курыксаң, урманга барма, син бу мәкаль белән килешәсеңдер ич, Әзһәр абзый? – дип сабыр гына тотынды ул һәм, колхозның якын киләчәктәге эшләрен күз алдына китереп булса кирәк, соңга таба ялкынлана төшеп исбатларга кереште.* Ф.Хөсни

**Ялкынланып алу** Бер арада ялкынлану. *Картаймыш көнеңдә тагын бер ялкынланып алырга насыйп икән әле...* Ш.Маннапов. *Аның аптырау-каушавы, киресенчә, хатынга кыюлык өстәп җибәрде булса кирәк, баягы оялчан күзләре янып, ялкынланып алдылар.* З.Хөснияр

**Ялкынланып йөрү** Һәрвакыт, гел ялкынлану. *Уртак идеяләр, хыяллар, милли хисләр белән ялкынланып йөри торган кешеләрнең шулай уйланып утырулары да тансык, кадерле.* Р.Фәйзуллин. *Кешеләребез, һичшиксез, әйбәт, тырышлар. Эш өчен ялкынланып йөрүчеләр.* М.Зарипов

**Ялкынланып килү** Аз-азлап, акрынлап ялкынлану. *Бу тойгы вакыт-вакыт эчтән ялкынланып килә, йөрәкне, бугазны кыздыра, эссесе битләргә чыкканы сизелә.* Ш.Камал

**Ялкынланып китү** Аз-азлап ялкынлану; тиз арада ялкынлану. *Минем йөрәгемдә аңа карата зур хиснең кечкенә чаткысы бар кебек иде һәм, якыная, белә төшкәч, көчәеп, ялкынланып китәргә тиеш кебек иде.* Ә.Еники. *--- аның үзендә дә элеккеге кебек кабынып, ялкынланып китү дуамаллыгы инде юк, ул яшьлектә томанда өретелгәндәй төсмерләнгән каен рәтләре арасында адашып калган күк.* А.Вергазов

**Ялкынланып кую** Аз гына, кыска вакытка ялкынлану. *Зәйни карт пөхтә итеп төзәтелгән ап-ак сакалын сыйпады. Күзләре ялкынланып куйды.* Р.Сәгъди

**Ялкынланып тору** Һәрвакыт ялкынлану; озак вакыт дәвамында ялкынлану. *Аның ялкынланып торган күз карашы, яшь, сылу йөзе, тубыгына җиткән кара толымнары, тулы, төгәл буйсыны бер карауда ирләр токымының аңын җуйдырыр иде.* Н.Фәттах. *Килеп җитте кайнар авазларың – Ялкынланып торган чын җырлар.* Р.Миңнуллин

**ЯЛКЫНЛАНЫП** *рәв.* Дәртләнеп, дәрт белән, хис белән. *Үзе ничек ялкынланып килеп кергән булса, шулай чыгып та китте.* Б.Рәхимова. *Инде бергәбергә куанып, ялкынланып кына яшисе дигәндә, менә сиңа...* Г.Каюмов

**ЯЛКЫНЛЫ** *с.* 1) Ялкынланып яна торган; көчле ялкыны булган. *Күккә ашкан андый ялкынлы учакны аның үзенә булдырып карарга иде.* К.Җәмит. *Куян, елый-елый, күл буендагы учакка сүз каткан: «Әй ялкынлы учак, шул явыз камышны яндыр әле!»* Р.Вәлиев

2) *күч.* Бик кайнар, көчле, дәртле (хис тур.). *Балачак мәхәббәте ул шундый ялкынлы хис икән, ул һич тә күңелдә тыныч кына ятарга яратмый, ул ташырга, атылырга юл эзли, аны кемгәдер сөйлисе, хәтта мактанасы, яшерен сөюеңне уртаклашасы килә икән.* А.Гыйләҗев. *Ялкынлы мәхәббәтемне тезләнеп аңлатулар, үгетләүләр дисеңме – берсе дә калмады.* З.Мәхмүди

3) *күч.* Тәэсирле, үтемле; фикерне үтемле итеп җиткерә торган (сөйләү, чыгыш ясау тур.). *Дөрес, ул үзе дә, кәефе килгән чакларда, бик ялкынлы, үтемле чыгышлар ясый торган иде.* Ә.Еники. *Әйе, ачуы чыкканда да тавыш күтәреп сөйләшми, кычкырышмый, йодрык төйнәп ярсый-ярсый чыгышлар ясамый, урам җыеннарында ялкынлы нотыклар томмый.* Р.Вәлиев

4) *күч.* Хисле, тәэсирле, үтемле; күңелгә үтеп керә, уйландыра, яшәү дәрте бирә торган (сүзләр тур.). *Ларисаның ялкынлы, хисле сүзләренә җавап итеп, ул аны әкрен генә, иплән кенә үпте, чын күңеленнән яратып иркәләде.* М.Вәлиев. *Ялкынлы җырлары белән Көч бирәдер яшәргә.* Л.Шагыйрьҗан. *Ялкынлы мәкалә. Ялкынлы шигырь*

5) *күч.* Ашкынып, дәртләнеп, ярсып эшли торган. *Чөнки С.Сүнчәләй шагыйрь дә, тәрҗемәче дә, драматург та, ялкынлы публицист та иде.* М.Мәһдиев. *Безгә А.Хәлим кебек ялкынлы публицист язучылар җитми.* Н.Шәрифуллин

6) *күч.* Көчле хис чагылдырган, белдереп торган; дәртле (караш һ.б.ш. тур.). *Чем кара мөлдерәмә күзләрнең ялкынлы карашы белән очрашып, егет бөтенләй өнсез калды.* Н.Сәйяр. *Аликның үзенә төбәлгән, әллә ниләр вәгъдә иткән ялкынлы, дәртле карашын күрми, аның бу ирдә бер эше юк.* Р.Габделхакова

7) *күч.* Хөрмәт, ярату, сагыну кебек хисләрне белдергән; хискә бай, тирән тойгылы, кайнар (сүз тур.). *Әлфиягә миннән ялкынлы сәлам тапшыр.* Н.Гыйматдинова

**ЯЛКЫНСЫНДЫРУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **ялкынсыну**. *Көзнең салкынча,*

*дымлы һавасы сулыш юлларын тагын да ныграк ялкынсындырды.* С.Зыялы. *Әлеге төркемгә кергән торган үсемлекләр башлыча ашказаны-эчәк юлларын ялкынсындыралар.* Агулы үсемлекләр

2) *күч.* Тәэсирләндерү; хисләндерү, ашкындыру, дәртләндерү. --- *тәгәрмәч шыгырдавы күңелгә әллә ниткән шом сала, болай да курка-курка яткан Фатыйманың йөрәген ялкынсындыра.* М.Хәбибуллин. *Ул гына шулай күңелне ялкынсындырырлык итеп сайрый ала.* Г.Гыйльманов

**Ялкынсындыра башлау** Ялкынсындырырга тотыну. *Алар бит тиресен корыта, ялкынсындыра башлый.* Сөембикә

**Ялкынсындырып җибәрү** Бераз ялкынсындыру. *Әмма ханымның чәчләреннән килгән хушбуй исе егетнең хисләрен тагын да ялкынсындырып җибәрде, һәм алар бер-берсенең кочагына тәмам чумдылар.* Ф.Яхин

**ЯЛКЫНСЫНУ** I *ф.* 1) Авырткан урын кызарып, шешеп китү. *Керфек төпләре ялкынсынган – ул да йокысыз төн үткәргән булса кирәк.* М.Хәсәнов. *Тайган кулбашны моңа кадәр шактый тарткалаганнар, күрәсең, шешенгән, ялкынсынган.* Ф.Яруллин

2) *күч.* Нинди дә булса сүз, күренеш һ.б.ш.дан күңелдә көчле кичерешләр уяну, тойгылар кузгалу, әсәрләнү; хискә бирелү; тәэсирләнү. *Юкса бу тынгысыз, ялкынсынган җанны коточкыч, кичеп чыккысыз кайгы басар иде.* З.Хәким. *Чакрымнарны адым итеп Барам сине үбәргә. Ялкынсынган йөрәгемне Тыеп торыймниләргә?* И.Сабиров. *Күңел ялкынсыну*

3) *күч.* Артык киеренке халәттә булу. *Ялкынсынган ми икеләтә-өчләтә көч белән эшли, яңадан-яңа уй катламнарын актара, яңадан-яңа хатирәләрне ачып кына тора.* М.Хәсәнов. *Бу, бер яктан караганда, гел уйланудан инде баш мие ялкынсынган кеше өчен әйбәт булып калды, бераз ял итеп, зиһене яктырып китте.* З.Мурсиев

**Ялкынсына бару** Вакыт үткән саен күбрәк ялкынсыну. *Кулының ялкынсына баруын күреп, борчыла башладык.* Кызыл таң

**Ялкынсына башлау** Ялкынсынырга тотыну. *Бүген алар яңа куркыныч учагын ачтылар: үпкә ялкынсына башлаган!* Г.Әпсәләмов. *Көн буе макияж белән торган күз кабагы кичкә таба ялкынсына башлый.* Ватаным Татарстан

**Ялкынсына төшү** Бераз ялкынсыну; тагы да ялкынсыну. *Күзләрең бүген тагын да ялкынсына төшкән*

**Ялкынсынып алу** Берара ялкынсыну. *Инде минем дә тумас борын ук үпкәм ялкынсынып алгач, безнең гаилә яңадан туган туфракка кайтып төшкән.* Т.Нурмөхәммәтов

**Ялкынсынып бетү** Бик нык ялкынсыну. *Куллар ялкынсынып бетте*

**Ялкынсынып калу** Берәр нинди сәбәптән, тәэсирдән, вакыйгадан соң ялкынсыну; ялкынсынган хәлгә килү. *Алай да, үпкәсе ялкынсынып калмасын дип, район хастаханәсенә алып барырга уйладылар.* Г.Бәйрәмова. *Йөрәк ялкынсынып калды Синең биргән назларыңнан.* В.Галиев

**Ялкынсынып килү** Аз-азлап, акрынлап ялкынсыну; ялкынсына башлау

**Ялкынсынып китү** Кинәт ялкынсыну; соңгы вакытта ялкынсыну. *Күз төпләре ялкынсынып киткән.* М.Хәсәнов. *Нәкъ шул көндә йөрәгем ялкынсынып китте, хәтта «скорый» чакырырга туры килде.* Г.Гыйльманов

**Ялкынсынып тору** Гел, әледән-әле ялкынсыну; әле, хәзерге вакытта ялкынсыну; озак вакыт ялкынсыну. *Яра, чынлап та, төзәлеп килә, тик әз генә ачык җире бар, ялкынсынып та тора.* З.Мурсиев. *Ялкынсынып торган яра тартылган кебек булса да, әле җөйләнеп үк бетмәгән, һаман әрни, сулкылдый.* Р.Мулланурова

**ЯЛКЫНСЫНУ** II *и. мед.* Билгеле әгъза, тукыма һ.б.ш.да кызару, шешү, үлекләү, эрозия һ.б.ш. симптомнар белән характерланган авыру халәт. *Аннары тезелеп китте төрле авырулар, дарулар, күзәнәкләр, ялкынсынулар, пневмонияләр, лейкоцитлар, эритроцитлар, хромосомалар, геннар, җеннәр...* Г.Афзал. *«Кояш җиләге» – бик югары сыйфатлы диетик ризык, көчле дәвалау чарасы, ул микробларны үтерергә, яраларны төзәтергә, ялкынсынуларга каршы торырга сәләтле, шуның аркасында, бүген дөньяның бик күп илләрендә аның кадерен беләләр.* Татарстан яшьләре

**ЯЛКЫТУ** *ф. к.* **ялыктыру**. *Беркөнне, ничектер, дәрестә аңа бик күңелсез булып китте, тик утыру ялкытты, җырлыйсы килә башлады.* Д.Каюмова. *Алдан әзерләгән үсентеләрен, орлыкларын, ризыгын төяп, шул кыска вакытка гына булса да, ялкыткан базардан, шәһәр шау-шуыннан үзенең бакчасына күчеп китә ул.* К.Кара

**Ялкыта бару** Акрынлап ялкыту; ялкыта башлау. *Аралашу ялкыта бара*

**Ялкыта башлау** Ялкытырга тотыну. *Аннары шигырьләрдә бер үк образларның, бер үк шигъри формаларның бик еш кабатлануы да ялкыта башлый.* Р.Миңнуллин. *Югыйсә юл озын, бер сүз сөйләшми кайтуы ялкыта башлый.* З.Мурсиев

**Ялкыта төшү** Беркадәр ялкыту; тагын да ялкыту. *Башта яратып тыңлыйсың, йокы баса башлагач, ялкыта төшә, ахыр чиктә күпкә китә башлый.* Шәһри Казан

**Ялкытып бетерү** Тәмам, бик нык ялкыту. *Аннары инде сәламәт яшәү өчен көрәшергә тотындык: шакымаган ишек, бармаган табиб калмады, үземнең сорауларым белән кайбер табибларны ялкытып та бетердем.* Кызыл таң

**Ялкытып җибәрү** Бераз ялкыту. *Инде ике атна буе диссертация язып, кичләрен диңгез һавасы сулап йөргән Хәрзанны бу көндәлек бертөрлелек бераз ялкытып җибәрде, һәм ул шимбә кичне кино карап чыгарга уйлады.* Г.Рәхим

**Ялкытып тору** Сөйләү моментында ялкыту; даими ялкыту. *Зәркәнттән күчеп китүемнең сәбәпләре күп җыелды, шуңа күрә ваклыклары белән сезне ялкытып тормыйм, үз эшегез дә муеннан.* Р.Мирхәйдәров

**ЯЛЛАНУ** *ф.* Билгеле шартларда нинди дә булса эшне башкарырга алыну. *Ул быел яздан көзгә кадәр Бикбулатларга хезмәтче булып ялланган.* Г.Бәширов. *Менә шушы көннән мин әтигә ат караучы булып ялландым.* А.Хәсәнов

**Яллана башлау** Ялланырга тотыну. *Ул анасы үлгәннән бирле хәллерәк кешеләргә яллана башлады.* Г.Бәширов

**Ялланып кую** Алдан яллану. *Яз көне үк күрше авыл байларына ялланып куйган икән ул.* Кызыл таң

**ЯЛЛА́У** *ф.* 1) Нинди дә булса эш башкару өчен, билгеле бер шарт белән кеше алу. *Казан хәтле Казаннан ике адвокат яллады.* Н.Акмал. *Авыру хатынны карарга Надыйр шәфкать туташы яллады.* Р.Мулланурова

2) Билгеле бер хак түләп, вакытлыча файдалануга техника алу, хезмәт күрсәтүне сорау. *Кеше алдында күңеле кителмәсен дип, баланы төрергә ефәк юрган алып бардым, җиңел машина яллладым.* Э.Шәрифуллина. *Монысы – Нарулның хәйләсе, яңа өй салам, чокыр казып бир әле, дип, ул техника яллады.* З.Мурсиев

**Яллап йөрү** Даими, гел яллау; озак вакыт дәвамында яллау. *Бер-ике еллар элек студент тулай торакларына теләсә кемнәр килеп, егет-кызларны эшкә яллап йөргәннәр.* Татарстан яшьләре

**Яллап карау** Ялларга тырышу; белү, сынау өчен яллау. *Башка авыллардан да хезмәтчеләр яллап карады Хәмзә.* Т.Нәбиуллин. *Эшчеләр яллап караган идек тә, түзмәделәр. Шәһри* Казан

**Яллап килү** Күптәннән бирле, эзлекле рәвештә, даими яллау. – *Ә син Островновларның гомер буена хезмәтче яллап килүләрен белми идеңмени? – диде Аржанов, аннары күзен хәйләле генә кыса төшеп: – Ялладылар инде, дус кеше, ялладылар...* М.Шолохов

**Яллап кую** Тиз арада яки алдан яллау. *Белмәссең, арада хәллерәге табылып, берәрсе эшкә дә яллап куяр.* Р.Максудов

**Яллый башлау** Ялларга тотыну. *Ул елларда ашлык бик уңып, колхозның исә үз көче белән генә ерып чыгарлык хәле булмаганда, читтән уракчылар яллый башлаганнар иде.* Н.Фәттах. *Хәлле ата-ана баласы өчен тән сакчысы да булып хезмәт итә ала торган гувернёрлар яллый башлаган.* Сабантуй

**ЯЛЛЫ** I *с.* 1) Яллап эшләтә торган. – *Яллы хезмәт кулланмадыңмы? – дип сораган.* М.Мәһдиев. *Чөнки, беренчедән, яллы хезмәт кулланмаганнар, икенчедән, аларны җибәрсәң, тегермәндә эшли белүче кеше юк.* Р.Вәлиев

2) Ялланган, ялланып эшкә алынган. – *Ахырзаман килде, ахырзаман! – дип кычкырып, яллы сакчылар, берсен берсе изә-сыта, тимер капка бигенә ябырылды...* В.Имамов. *Күпчелек авылларда кайчандыр гөрләп торган клублар күптән ябылып, читтән килеп эшләүче яллы эшчеләрнең вакытлы торагына әйләнгән.* Татарстан яшьләре

**ЯЛЛЫ** II *с.* Ялы (III) булган. – *Сугыш хикмәте инде бу, Ярман җиреннән әллә ниткән яллы бүреләр килгән, безнең бу тирәдә туп шартламагач, аларга тыныч инде, фәлән инде, төгән инде... – дип, бу хәбәрне ул көннәрдә авыл буенча Хәбирә карчык таратып йөрде.* М.Мәһдиев. *Яллы сыртлан*

**ЯЛМАВЫЗ** *и.* **1.** *миф.* 1) Төрки мифологиядә кешеләр ашаучы куркыныч мифик зат. *Ялмавыз җиде чакрымнан теле белән ялмап йотар.* Әйтем. *Берәр ялмавыз яки дию посып ятмасын!* Р.Батулла. *Мин анда явыз Ялмавыз ролен башкардым.* Шәһри Казан

2) *күч.* Ачкүз, туймас тамак, туймас күз. – *Кит моннан, ялмавыз! – дип, Годунов аны этеп җибәрде.* М.Әмирханов

**2.** *с. мәгъ.* 1) *миф.* Юлында очраганнарны ашый торган; кеше ашый торган. – *Миннән дә, ерак галәмдәге Гөләндәмнән дә ялмавыз карчык чыгарга тиеш иде... – диде Ак әби, көрсенеп.* А.Тимергалин

2) *күч.* Барысын да юк итә торган; куркыныч. *Ай, ничек карыштылар ул китап-журналлар ялмавыз ялкынга...* А.Тимергалин

**ЯЛМАН** *и. диал. к.* **кушаяк**. *Ялман керт-керт тауга менә, керт-керт таудан төшә.* Халык афоризмнары

**ЯЛМАНУ** *ф.* 1) *к.* **ялану**. *Ә кайбере учына кат-кат салдырып, мыегына ботка буялган мәчедәй, озак ялмана.* Ф.Яруллин. *Шунда ук теләнчеләр, аксак-туксаклар, каралар... тамагы ач башка төрле ыбыр-чыбыр ялманды.* Н.Фәттах

2) *сөйл.* Ялаштыру, кат-кат ялау. *Ә иң кечкенә сеңлесе, рулетның үзенә тигән өлешен ялмана-ялмана: – Алма апай, ә конфет алып кайтмадыңмы? – дип елышты.* М.Мәһдиев. *Аннары, башак өстәп салуга, олы җиленен селкетеп, озын мөгезләрен куркыныч селтәп, кара кызыл сыер чыга, һаман көрпә ялманган сарыкларга ачуланып, аларны сөзеп-сөзеп җибәрә.* Д.Булатова

3) *күч.* Берәр нәрсәне сарып алу, үрләү. *Ут беразга гына сүрелгән кебек булды да, ялкын телләре төпнең яңгыр үтмәгән эченнән ялманып өскә үрләделәр.* А.Гыйләҗев. *Кызгылт сары ялкын телләре, зәһәр еланнардай ялманып, соргылт комсу туфрак чәчрәгән броня өстендә биешә, алар шуышып узган урында металл кызып, күкселләнеп кала иде.* М.Маликова

4) Икенче берәү ашаганга кызыгып, ымсынып, иреннәрен ялап тору. *Малайлар яннарына килеп баскач, иркә песи сыман кыланып, я муеннарын ышкып сырпаланалар, я кытыршы иреннәре белән ялманалар.* В.Имамов

5) *күч.* Кызыгу; башкаларда булганны теләү. *Шулай инде, акчаң булмаса, ялманасың инде.* Т.Миңнуллин. *Без, нигездә, ипи телеменә ялманып иҗат итә торган кавем.* Р.Фәйзуллин

6) *күч.* Ялагайланып, өмет итеп, көтеп йөрү. *Әгәр дә без шул көч-куәтебезне файдалы эшләргә җигеп, республикабыз табышын көннән-көн арттыра барсак һәм үз байлыкларыбызның күпчелек өлешен үз халкыбыз мәнфәгатьләренә тотуга ирешсәк, киләчәктә бюджет бәлеше тирәсендә болай ялманып-ялварып, теләнеп тә йөрмәс идек.* Р.Вәлиев. *Җаһилләр йөри үзләрен Фәрештәгә тиң күреп. Ялманып тамак туйдыра Ялагайлары, өреп.* Э.Шәрифуллина

**Ялмана башлау** Ялманырга тотыну. *Шуны гына көткәндәй, мәче ялмана башлады.* Ялкын

**Ялманып алу** Берара, аз гына ялману. *Касыйм ялманып алды, күзләре майланып китте, иреннәренә мәгънәле елмаю җәелде.* М.Маликова. *Авыл мәчеләре телләрен чыгарып, иреннәрен ялманып алдылар.* Л.Лерон

**Ялманып йөрү** Даими, гел ялману; озак вакыт дәвамында ялману. *Әдәбият белән реаль тормыш үзара ярышып, бер-берсеннән өйрәнеп, казна караклары, мафия, азгынлык корольләре һәм королевалары, алар янында ялманып йөрүче мескеннәр үрчетә.* Р.Шәрәфиев

**Ялманып кую** Бер мәртәбә ялману; тиз генә ялману. *Трамвайга утырып тулай торакка баралар иде, бер тукталышта Лениза, кулындагы ромашкалар бәйләме аша үрелеп, ачык ишектән урамга карады да: – Морожный саталар, – дип ялманып куйды.* М.Маликова

**Ялманып тору** Әле, хәзер ялману; озак вакыт дәвамында ялману. *Аның баядан бирле ялманып торганын күңелле күзәткән Басыйр Бариевич арткы утыргычка ымлады: «Ал. Сиңа. Бүләк».* А.Гыйләҗев

**ЯЛМА́У** *ф.* 1) *к.* **ялау** I. *Даян ирен тирәләрен ялмады да, яңакларын күпертеп, Байдар кыяфәтенә кереп, тезеп китте: – Сания дә качак, мин дә качак, урлап, ятак бүлдек.* В.Имамов. *Ләйлә дә тик тормады, Иреннәрен ялмады.* Л.Лерон

2) Бик тиз, зур-зур кабып ашау; ашап бетерү, кабып кына йоту. *Теге көнне без тәкәне ялмаган кебек, кимерә-кимерә ашарга тиеш ул безне.* Әкият

3) *күч.* Нинди дә булса өслеккә иңләтеп таралу, җәелү. *Мич эчен ут-ялкын ялмагач, Йөрәккә үрләде ут теле ---.* Ф.Гыйззәтуллина

4) күч. Бик тиз эшләп бетерү. *Куркып тормый, ялмый гына бит ул*

5) күч. Тиз арада юк итү, бетерү, юкка чыгару. *Ут нигезгә кадәр ялмагач, хуҗа, кулын күкрәгенә кушырып: – Гаепләмәгез инде, җәмәгать, өем*

*кечкенә иде, пожары көчле булмады, – дигән, имеш.* Н.Гыйматдинова

◊ **Ялмап кабу** Бөлдерү; һәлак итү. *Капитал бит сезне дә ялмап каба, Сез йөрисез ике арада ялап таба.* Г.Камал

**Ялмап алу** Тиз генә ялмау. *Зур янгыннар вакытында төтен болытының үзендә дә ут кабынып киткәли, чөнки агач янганда чыккан төтендә күп микъдарда үтә вак дегет тамчылары була, һәм вакыт-вакыт бу болытны ялкын ялмап ала.* А.Тимергалин

**Ялмап бетерү** Барысын да ялмау. *Сугыш ялмап бетергәнче, Сиңа бирим, кыз бала.* М.Шабаев. *Ә бүген, мин юкта, бүлмәдәш малайлар бөтенесен ялмап бетергән!* В.Нуруллин

**Ялмап килү** Аз-азлап, акрынлап ялмау. *Ул вакытта зур кыз бөтен мич алдын ялмап килгән ялкын белән көрәшә иде инде.* Л.Ибраһим-Вәлиди

**Ялмап китү** Кинәт ялмау; тиз арада ялмау. *Ялмап китә алмый утлар аны, Басып китә алмый сулар аны, Чайпалдырмый җаным чак тота...* Ф.Җамалетдинова

**Ялмап кую** Бер тапкыр ялмау; тиз генә ялмау. *Иренен ялап куйган, Тагын бер Ялмап куйган. Күренеп тора инде: Куянның тамак туйган!* Р.Миңнуллин. *Сарымсаклап торып, каяндыр ялт кына табып китерелгән салкын сарык ботын ялмап куйды.* Д.Булатова

**Ялмап тору** Даими, әледән-әле ялмау; әле, хәзерге вакытта ялмау. *Җизни, әйтәсе сүзен тәмләп карагандай, иреннәрен ялмап торды ---.* Г.Бәширов. *Көннәрне ялмап кына тора эш-мәшәкать дигән нәрсәләр!* А.Гыйләҗев

**Ялмап чыгу** Барысын да рәттән ахырына кадәр ялмау. *Өчиле тегермәненең ике ягында җәелеп яткан, печәне билгә җиткән ике болынны ике көн эчендә ялмап чыгып, әллә ничә кибән өеп куялар иде.* Г.Ахунов. *Шул ничәмәничә гектар җирне ялмап кына чыга торганнар иде бит... кул белән, бернинди машинасыз...* Н.Фәттах

**Ялмый бару** Рәттән ялмау; торган саен ныграк ялмау. *Торган саен йөрәкне ялмый барган паразитларның көче арта.* Шәһри Чаллы

**Ялмый башлау** Ялмарга тотыну. *Озак та үтмәде, имән ботакларын ялкын телләре ялмый башлады.* Н.Хәсәнов. *Святослав, казаннан гына алынган кайнар итне бүлергә әзерләнгәндәй, җиңнәрен сызгана, иреннәрен ялмый башлагач, Ибраһим кабалана-кабалана тезде: – Каганны чәнчелдереп төшерсәң, үзеңә дан.* В.Имамов

**ЯЛПАК** *с. диал.* 1) Яссы, җәенке, җәлпәк. *Йөгерек инеш юып шомарткан ялпак ташларның көндезге җете аклыгы да үтә тоныкк.* М.Хуҗин. *Бәла аяк астында ята бит: Зәйнулла пневматик чүкеч белән заготовка чүкегәндә, сандалга ялгыш әйләндереп салынган ялпак тимер кисәге балта астыннан ычкынып китеп, аңын җуйдырырлык дәрәҗәдә иңбашына килеп кадалган иде.* Д.Бүләков

2) Җәенкеләнеп киткән. *Кичке урманның һәм чатнап янган учакның һич кабатланмас хозурлыгы бар иде: кызгылт яктылык шәүләсе сихри эңгергә төренгән ялангач юкә һәм ялпак ботаклы чыршылар буйлап үрмәли дә дереләдәп калтырап түбәнгә шуыша.* А.Вергазов

**ЯЛПАКЛАНУ** *ф.* Җәенкеләнү, җәелү. *Кич булса, күп вакытта казарманың көнбатыш ягындагы кирпеч стенага аркасы белән сөялеп тезләрен кочаклый һәм, казармадан йөз сажиннар читтә ялпакланып киткән чокырдагы буада су коенучыларны сәгатьләр буенча карап, көй тартып утыра...* Ш.Камал

**Ялпаклана бару** Ялпаклануга таба бару, әкренләп ялпаклану. *Имәннең ботаклары ялпаклана бара*

**Ялпаклана башлау** Ялпакланырга тотыну

**Ялпаклана төшү** Беркадәр ялпаклану; тагын да ялпаклану. *Чыршының ялпаклана төшкән яшь ботаклары*

**Ялпакланып бетү** Тәмам ялпаклану; бик нык ялпаклану

**ЯЛПАЮ** *ф. диал.* Матурлану, чибәрләнү, әйбәтләнү, күркәмләнү. *Кыз үзгәреп киткән, ялпайган*

**ЯЛСЫЗ** *рәв.* **1.** 1) Ял итмичә. *Ничә төне ялсыз үтте аның, Йөрәк көче күпме түгелде.* К.Булатова. *Ачлытуклы, ялсыз үткән еллар үзенекен итә.* Т.Нәҗмиев

2) Бер дә туктап тормыйча; хәрәкәтен, эшен туктатмыйча. *Машина да ялсыз эшли алмый бит.* Р.Миңнуллин. *Соңгы көннәрдә техника ялсыз диярлек эшли.* Туган як

3) Ялга, тәнәфескә туктамыйча; төшке аш вакытында яки ял көннәрендә ял итмичә, эшне туктатмыйча. *Күпфункцияле үзәк ялсыз эшли.* Шәһри Чаллы. *Май бәйрәмнәрендә Казанның дүрт зур базары да гадәти режимда, бернинди ялсыз эшләячәк.* Татарстан яшьләре // Тәүлек буе; төшке аш вакытында һәм төнлә ял итмичә, эшне туктатмыйча. *Ялсыз эшли торган кибетләр дә бик күп бит хәзер.* Р.Вәлиев. *Шәһәрнең стационарлары һәм травмпунктлары ялсыз эшләячәк.* Ватаным Татарстан

**2.** *с. мәгъ.* Ял итми (ителми) торган; ял итмичә үткән. *Һәр эшкә зур җаваплылык белән карый торган кеше буларак, әлеге китапны язганда да, көнне-төнгә ялгап, ялсыз һәм йокысыз чор башланды аңа...* Т.Нәҗмиев. *Әйтерсең гомеренең йокысыз, ялсыз өлеше узган шушы бина аның өстенә аварга тора иде...* Х.Ширмән

**ЯЛТ** *иярт.* **1.** Тиз һәм кинәт кабынып, кискен яктырып китү рәвешен белдерә; *к.* **гөлт** (*2 мәгъ.*). *Ялт! Шул мизгелдә утлар да кабынып китте!* Р.Вәлиев

**2.** *рәв. мәгъ.* Тиз, кинәт; җәһәт кенә, җитез генә (эш, хәрәкәт һ.б.ш. тур.). *Ул очлы ияген каккандай итеп исәнләште, машина ишеге ялт ачылды, төргәк кулдан кулга күчте.* А.Гыйләҗев. *Васил түзмәде, ялт торды да Ләйсәнгә урын бирде.* В.Нуриев

**3.** *хәб. функ.* Берәр эшне җитез башкару турында. *Идән астыннан күземә бер уч туфрак – ялт!* Ш.Камал

**4.** *кис. мәгъ.* Чалт. *Ялт аяз көнне тып та тып тамчы тамамы соң?* Ш.Галиев

**ЯЛТАК** *и. к.* **ялагай**. *Ялтаклар күбәеп китте*

**ЯЛТАКЛАНУ** *ф. к.* **ялагайлану**. *Ялтакланырга гына булсын аңа*

**ЯЛТ ИТҮ** *ф.* 1) Ялтырау, ялтырап алу. *Борынгылар, ялт итеп киткән яшен утыдай күреп өлгереп булмый торган «абага чәчәге» кешене күзгә күренми торган итә, дип ышанганнар.* А.Тимергалин. *Кыз, елга өстеннән күзен алмыйча гына, яшенгә карата әйтелә торган әфсенне исенә төшерде: «Ялт итте, йолт итте, Елгага төшеп китте. Тфү, тфү, тфү!»* Г.Гыйльманов

2) Яктыру, ачылу, яктырып алу. *Каршыдагы ике учак арасы да ялт итеп тора – моннан, күренми генә, тычкан да үтеп китә алмастыр.* Л.Зөлкарнәй. *Зәринәне иң шаккатырганы шул булды: бөтен җир ялт иткән!* Г.Әдһәмова

3) Чистару, матураю, пөхтәләнү. *Апак такталарны әлифләп тә җибәргәч, веранда курчак өе кебек ялт итте.* Ф.Яруллин. *Урамда, ишегалдында эш тәмамланды, бөтен тирә-як ялт итте.* Г.Гыйльманов

◊ **Ялт итеп** 1) Аермачык, төп-төгәл, күзгә бәрелеп. *Без вокзалга кич кенә килеп җиттек, ә сәгатьнең бөтен цифрлары ялт итеп күренеп торалар*

*иде.* А.Алиш; 2) Матур, чиста, килешле итеп киенү, күренү турында. *Ялт итеп торган бу чибәр кеше безнең белән елмаеп исәнләште дә түргә узды.* Н.Фәттах. – *Чибәрме соң? – Ялт итеп тора!* Ф.Баттал. **Ялт иттереп** Яхшылап, матур итеп; тиз генә. *Ул көнгә дугаларны, тарантас-тәртәләрне һәйбәтләп, ялт иттереп кап-кара лакка буяп куябыз.* А.Хәсәнов. **Ялт иттерү** 1) Чистарту, пакь итү, ялтырату. *Бакчаны ялт иттерде!* М.Шабаев. *Ярты сәгатьтә бөтен бүлмәсен ялт иттердем.* Г.Галиева; 2) Бик тиз эшләп ташлау, тиз һәм пөхтә башкару. *Кая, китер әле, үзем ялт иттереп тегеп ташлыйм.* А.Алиш. *Без күпме җыенып булдыра алмаган эшне күз ачып йомганчы ялт иттердең бит.* Г.Әпсәләмов; 3) Бик тиз ашап, эчеп бетерү. *Әнисенең аяк тавышлары тынуга, Һади ипи белән сөтне ялт иттерде дә салкын су белән генә чынаяк чокырын юып куйды.* А.Гыйләҗев. *Бик ачыккан иде шул Баһадир: дөгенеке дип тормады, янә бер савыт ботканы ялт иттерде.* Л.Лерон; 4) Кинәт кемнең дә булса яңагына сугу. *Көтмәгәндә абыйсы ялт иттерде*

**Я́ЛТ-ЙОЛТ** *иярт.* **1.** 1) Төрлечә җемелдәү, ялтырау рәвешен белдерә. *Хрусталь пыялалар ялт-йолт ялтырап кына торалар.* Д.Аппакова. *Ул һәр сүзен әйткән саен, давыллы күктә ялт-йолт яктылыклар уйнаклады.* Р.Хисмәтулла

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Тиз генә; бик тиз. *Ул да булмады, күзен ялт-йолт уйнатып, Гыйльми Салихы үзе килеп чыкты.* А.Гыйләҗев. *Ялт-йолт өстенә киенде дә, келәттән он-фәләннәр аласы бар, дигән булып, картны иертеп чыгып та китте.* М.Мәһдиев

2) Шикләнеп, куркып, тиз-тиз (карау, карану тур.). *Аннан, кеше-мазар юкмы дип, тирә-ягына ялт-йолт каранып алды да, чалбар кесәсеннән аракы шешәсен чыгарып, койма буенда яткан зур ташка челпәрәмә бәреп ватты.* Ә.Еники. – *Әйдә инде, әни, иртәгә унбиш минутка иртәрәк килерсең, – дип ялынды кызы, бүлмәдәге башка апаларга да ялт-йолт карап.* Д.Бүләков

**3.** *и. мәгъ.* Җемелдәп, ялтырап торган берәр әйбер. *Күктәге ялт-йолтларның коточкыч күкрәүләре килеп җитте.* Р.Хисмәтулла. *Дөрес, ул дәшмәде, ләкин эчендә шактый җыелды... Ярсынган миендә бу шау-шулар озак вакыт тынмады, ниндидер ачык ялт-йолтлар күзен авырттырды.* Рөстәм Вәлиев

**Я́ЛТ-ЙОЛТ ИТҮ** *ф.* Җемелдәү, ялтырау. *Коеп яңгыр ява, әледән-әле нәрсәдер дөбер-шатыр килә, ялт-йолт итеп яшен яшьни.* Н.Фәттах. *Абыем исә биленә пычагын кыстырып алган, чәч алырлык үткер йөзе көн яктысында ялт-йолт итә.* Д.Бүләков

**Я́ЛТ-ЙОЛТ КИЛҮ** *ф. к.* **ялт-йолт итү.** *Киң, таза күкрәкләре, янбашлары ерактан ук йомрыланып күренә, йөгәнендәге, эшлиясендәге җизләре иртәнге кояшта ялт-йолт килә.* Н.Фәттах. *Аннары күк күкри башлады, ялт-йолт килеп яшен яшьнәде.* Р.Батулла

**ЯЛТЫР** *иярт.* **1.** 1) Ялт-йолт, җемҗем итеп җемелдәп, ялтырап китү рәвешен белдерә. *Ялтыр да гына ялтыр ни ялтырый?* Җыр

2) Кинәт кенә яңакка сугып җибәрү рәвешен белдерә

**2.** *с. мәгъ.* 1) Ялтырап торган. *Тегесенең тар, ялтыр маңгае кызарып чыкты, күзләре мелт-мелт йомыла башлады.* К.Кәримов. *Бәләкәй чагында ул ялтыр калай кисәкләре белән бизәлгән шушы сандыкны ачып актарынырга яраткан, бу гадәтен үсә төшкәч кенә ташлаган.* Г.Якупова

2) Пеләш. *Аның ялан ялтыр башы фуражкасыз, күлмәк якалары каптырылмаган.* А.Алиш. – *Бүген дә эләгә алмасам, кайтам да китәм, – диде ялтыр башлы, тәбәнәк гәүдәле директор.* М.Мәһдиев

3) Ялангач, капланмаган; ачык. *Бибинур дәшми, ялтыр, чиста маңгаена юешләнеп төшеп ябышкан чәчләрен кул сырты белән күтәреп кенә куя.* А.Гыйләҗев

4) *күч.* Ялт-йолт иткән, очкынлы, уйнаклап торган; йөгерек (күзләр тур.). *Ялтыр күзләре гел моңа карап торалар...* Г.Ибраһимов. *Ярый әле кичкә кырын карасу йөзле, ялтыр күзле Харун килеп керде.* Т.Нурмөхәммәтов

**3.** *и. мәгъ.* 1) Ялтыравык; ялтырап тора торган берәр нәрсә. *Күңелләрнең төбен актарып чыгарырлык матур җыр яңгырый, ләкин аны төнге клубның алдаткыч шау-шуы, ялган ялтырлары күмә.* Кызыл таң

2) *зоол. к.* **ялтыр коңгыз**. *Зур ялтыр. Талымсыз ялтыр*

**ЯЛТЫРАВЫК** *и.* **1.** 1) Ялтырый торган нәрсә. *Кайберәүләр болай да әллә нинди ялтыравыклар белән бизәлгән затлы күлмәкләренә туры китереп, алтын-көмеш беләзекләрен, йөзекләрен киеп куйганнар, чәчләрен әллә ниләр кыландырып бетергәннәр.* Г.Тарханова

2) Берәр нәрсәгә хас булган ялтырау үзенчәлеге. *Гөлбану күрде: икенче катта яшәүче Чулпаниянең тәрбиячесе Зөбәрҗәт апасының алдындагы таш савытларда, асылма лампаның бөтен яктылыгын үзләрендә чагылдырып, елык-елык итеп, төрле төстәге ялтыравыклар җемелди.* М.Хәсәнов

3) Күз кабакларына, иреннәргә, тәнгә сөртү һ.б. өчен кулланыла торган ялтырый торган косметика чарасы. *Сиңа бары тушь, бераз кершән, иреннәргә табигый төстәге ялтыравык кына кирәк.* Матур буласың килсә

4) Гадәттә балчык яки фаянс савытларның өстенә йөгертелә торган ялтыравыклы эретмә; глазурь. *Чүлмәкләргә ялтыравык йөгертү*

5) *күч.* Тышкы ясалмалылык; тыштан яхшы итеп күрсәтә торган ясалма нәрсәләр, тышкы бизәкләр. *Ул моны инде әллә кайчан күңеле белән аңлагандыр, шуңа күрә тышкы ялтыравыкларга, дөньяның бәясе тиз төшә торган кыйммәтләренә артык кызыкмыйдыр, төрле шаукымнарга бирелмидер.* Т.Әйди. *Ләкин аларның холык-табигатьләре нәкъ менә бу хикәядәге кызныкы сыман: алар гадилектән курка, чиркана, болар ялтыравыкка, купшылыкка мөкиббән!* М.Вәлиев

**2.** *с. мәгъ.* 1) Ялтырый торган, ялтырап торган, ялтыр. *Ул әледән-әле магазиннарга керде, шүрлекләргә тезеп куйган ялтыравык ботинкаларга, курчакларга, костюмнарга, төрле бизәктәге материя төргәкләренә карап торды.* Н.Фәттах. *Түр башында, олы ялтыравык өстәл артында, коңгырт-соры чәчле, күзлекле, өлкән яшьтәге абзый утыра.* Т.Галиуллин

2) *күч.* Шома, таза, тук. *Фойе һәм буфет залында – ялтыравык битле яшьрәк байлар, сәүдәгәрләр.* Ш.Камал. *Кыз Гайфарның шома ялтыравык битенә бармак очларын тидерде, монысы да мизгелнең мизгелендә булды.* М.Хуҗин

3) *күч.* Ясалма, артык купшы, матур тышлы. *Алданганны аңлап алдык соңга калып, Ә югыйсә рәхәт иде яшәүләре Ялтыравык ялган белән ялкынланып.* Г.Мөхәммәтшин. *Туфан нәзакәтле, купшы, ялтыравык сүзләр эзләп тормый.* Р.Рахмани

**ЯЛТЫРАВЫКЛА́У** *ф.* 1) Нәрсәнең дә булса өстенә ялтыравык йөгертү, глазурь белән каплау. *Савыт-сабаны ялтыравыклау*

2) *күч*. Тышкы яктан матурлау. *Чынбарлыкны ялтыравыклап күрсәтү*

**Ялтыравыклап алу** Аз гына ялтыравыклау; берара ялтыравыклау

**Ялтыравыклап җибәрү** Сизелерлек ялтыравыклау; бераз ялтыравыклау. *Чүлмәкләрне ялтыравыклап җибәрәсе генә калды*

**Ялтыравыклап кую** Ялтыравык хәлгә китерү; алдан ялтыравыклау. *Чәчләрен ялтыравыклап куйды*

**Ялтыравыклап тору** Даими ялтыравыклау; сөйләү моментында ялтыравыклау

**ЯЛТЫРАВЫКЛЫ** *с*. 1) Ялтырап торган. *Өстенә – бик ук ятышмый торган яңа костюм, башына – салам эшләпә, аягына ялтыравыклы ботинкалар кигән*. И.Юзеев. *Каян алгандыр – биленә ялтыравыклы төймәләр белән бизәлгән киң каеш булыр иде*. М.Хәсәнов

2) Ялтыратылган; ялтыравык белән бизәлгән. *Ялтыравыклы чыршы уенчыклары янында китә алмый инде ул шулай*. Ялкын

3) *күч*. Тыштан ялтырап, матур булып күренгән, ләкин үзе ясалма булган, әһәмиятсез. *Тормышның кайбер ялтыравыклы якларына кызыгып, үзебезне югалтмыйк!* Р.Сәгъди. *Аны ялтыравыклы тормыш үзенә тиңрәк тарта*. Ә.Закирҗанов

4) *күч*. Матур һәм йомшак итеп, нәрсәгә дә булса өметләндереп әйтелгән, ләкин чынында ялган булган. *Хикмәт ялтыравыклы вәгъдәләрдә түгел, ә гамәлдә: гамәл ни күрсәтер бит әле*. Ә.Еники. *Вакыт-вакыт ялтыравыклы, ләкин буш сүзләр белән декламация сөйләргә тотына*. Л.Ихсанова

**ЯЛТЫРАП** *рәв*. Ачык йөз белән, елмаеп. *Ике көннән соң, дүшәмбедә, кич Әгъзам гомуми торакка ялтырап килеп керде*. Д.Каюмова

**ЯЛТЫРАТКЫЧ** *и*. Берәр нәрсәне ышкып, шомартып ялтыратканда кулланыла торган махсус әсбап, материал һ.б.ш. әйбер. *Әнә, шкаф астында идән ялтыраткыч, ике аягыңа икене ки*. Р.Батулла. *Ялтыраткычны үзеңә дә ясарга була*. Заман сулышы

**ЯЛТЫРАТУ** *ф* 1) Яктылык бирү, яктырту. *Кояш та еракта, Усия урманнарыннан, томанланып торган Казан шәһәренең биек йортларының түбәләрен ялтырата-ялтырата батарга якынлый*. Һ.Такташ

2) Ялтырый торган итү, ялтыравыклы итү. *Әлеге маска чәчне ныгыта, тукландыра, ялтырата һәм йомшарта*. Сөембикә. *Кимендә биш минут чәчләрне тарап, бармаклар белән массаж ясау баш тиресендә кан әйләнешен яхшырта, чәчләрне ялтырата*. Кәеф ничек?

3) Нәрсәне дә булса ялтыраганчы чистарту, шомарту; ялтыравык хәлгә китерү, матурайту. *Ботинкаларын әйбәтләп ялтыратты, ә аннары эченә хушбуй сибелгән түбәтәен киеп, көзге каршысына килеп басты*. Ф.Яруллин. *Аты белән эшен бетергәч, үзенең коралларына тотынды – ышкыды, ялтыратты, кайрады*... Н.Фәттах

4) Тышкы яктан матурлау, чынбарлыкта булганнан әйбәтрәк итеп күрсәтергә тырышу. *Үз почмагын гел ялтырата инде ул шулай*

5) Очкынландырып, уйнатып карау; мутландыру (күзләр тур.). *Көянтә кашлы көяз хатын зәңгәр күзләрен әле һаман һавалы ялтырата иде. Т.*Әйди

6) Кызыгып, сокланып карау. *Кызыктылар безнең машинага. Синең Фәсахетдинең дә күзен ялтыратты!* М.Хуҗин

7) Кылыч, штык һ.б.ш.ны һавада тизтиз селтәп күрсәтеп алу; һөҗүмгә әзер булу; янау, корал белән уйнау. *Шулай дип уйларга өлгермәде, ул адәм Фәхри булды да, кулындагы зур пычагын ялтыратып, боларга таба атлый башлады*. Г.Ибраһимов. *Акъегет Тимерҗанның артыннан кочаклап ала, кинжалын ялтыратып, куркыткан булып шаяра*. А.Гадел

8) Кирәкмәгән, тиеш булмаган урында яки вакытта, яки тиешеннән артык нәрсәне дә булса ачу, кеше күрерлек итү. *Ап-ак тешләрен ялтыратып елмаю аңа бик килешә*. В.Имамов. *Шәрә аяк-ботларын ялтыратып, гөрселдәп караватына килеп утырмасынмы?!* Г.Гыйльманов

9) *сөйл*. Кемнең дә булса яңагына каты итеп сугу. *Икенче көнне Хәбирәсе кирәген бирде Әзһәренең, яңагына ялтыратты*. Ф.Яхин. *Эчемлекләр алган булды, аулакта утырды, һич булмаса бер кочаклыйсы булган, яңакка ялтыратса ялтыратыр иде*. К.Кара

10) *күч*. Тиз ашап бетерү, калдырмыйча ашау, сыптыру. *Яхшы аш әрәм калганчы, яман корсак ярылсын, дип, анысын да ялтыратты Илшат*. К.Кара. *Уяну белән, ярты чуен итсез борчак боткасын ялтыраттым*. К.Кәримов

**Ялтырата бару** Бер-бер артлы, рәттән ялтырату. *Алдына куйган ризыкны ялтырата бару*

**Ялтырата башлау** Ялтыратырга тотыну. *Ә инде Сәрбиназ апа идән паркетын ялтырата башласа, ул көнне аяктан егылмый туктамый ул*. Ф.Яруллин

**Ялтырата төшү** Бераз ялтырату: тагын да күбрәк ялтырату. *Ялтырата төшсәң, ярый чорт та, Тема гына булсын җырларга*. Г.Афзал

**Ялтыратып алу** Тиз генә, кыска вакыт эчендә ялтырату. *Кыз күзләрен шаян ялтыратып алды*. А.Гыймадиев

**Ялтыратып бетерү** Бик нык ялтырату; барысын да ялтырату, ялтыратуны тәмамлау. *– Бик чиста халык, анакаем, корымга баткан бөтен кәстрүлләремне ялтыратып бетерделәр, – ди*. Ф.Җамалетдинова

**Ялтыратып җибәрү** Тиз генә ялтырату; бераз ялтырату. *Ана кеше мондый мәсхәрәне күргәч тыела алмады, улының яңагына ялтыратып җибәрде*. В.Имамов

**Ялтыратып йөрү** Гел, даими ялтырату; озак вакыт дәвамында ялтырату; әле, хәзер ялтырату. *Җыештыручы хатыннар җиһазларны, стеналарны гел ялтыратып йөрүдә*. Татарстан яшьләре

**Ялтыратып карау** Ялтыратырга тырышу. *Баштан бер яфракны гына ялтыратып карагыз*. Заман сулышы

**Ялтыратып килү** Күптәннән бирле эзлекле рәвештә ялтырату; ялтыратып бетерүгә якынлашу. *Айдар савыттагы җиләк вареньесын ялтыратып килә иде инде*. Р.Бәшәр

**Ялтыратып кую** Ялтыраган хәлгә китерү. *Үз почмагын һәрвакыт җыештырып, ялтыратып куяр иде*. Д.Салихов

**Ялтыратып тору** Даими ялтырату; сөйләү моментында ялтырату. *Манара очына саф көмештән ай куйганнар, аны ел саен чистартып, ялтыратып торалар икән*. А.Тимергалин

**Ялтыратып чыгу** Һәрберсен бербер артлы ялтырату; һәммәсен тулысынча ялтырату. *Кирәк икән, бармак белән сыпырып, савытның кырыентөбен ялтыратып чыгабыз*. Маяк

**Ялтыратып яту** *сөйл. к.* **ялтыратып тору**. *Кәстрүлләрне ялтыратып ята идем*

**ЯЛТЫРАТЫП** *рәв*. Бик чиста итеп, пөхтә итеп. *Бер килгәндә ә дигәнче ике катның да идәннәрен ялтыратып юып чыга, икенче тапкыр керләрен чайкап бирә, өченчесендә янә нидер эшли*. С.Поварисов

**ЯЛТЫРА́У** *ф*. 1) Җемелдәү, ялтйолт итеп тору. *Монысының да алмазы*

*шулай ялтырый микән?* А.Гыйләҗев. *– Ут түгел ул, бүре күзләре шулай ялтырый! – диде Мәхмүт.* В.Нуруллин

2) Яктырып-яктырып алу, яктылык чәчү; якты булып күренү. *Галимҗан чыгып киткәч, кара болыт таралып, әнә шул якты кояш ялтырагандай тоелган иде.* С.Поварисов. *Яшеннәр ялтырар, яңгырлар гел явар, Күкләрнең авазы яңгырар.* З.Хәким

3) Күренү, сизелеп тору, чагылу (мәс., йөздә, кыяфәттә). --- *һәммәсенең йөзендә шул мәсләк аклыгыннан нур балкый, иман нуры ялтырый иде.* Г.Исхакый. *Тимофеевна кып-кызыл чырайлы, шуның өстенә кабартма чаклы иреннәрендә бер мыскал иннек сылаган, күзләрендә әдәпсез шатлык ялтырый.* Р.Батулла

4) *сөйл.* Аермачык булып күзгә ташлану. *Тузанлансак та үзебез, Ялтырый бит эш, менә!* Ш.Галиев. *Оста художник кулында һәр деталь нәтиҗәле ялтырый, күркәм образ гәүдәләндерүгә хезмәт итә.* Ф.Хатыйпов

5) *күч.* Тышкы яктан матур күренү, әйбәт булып тоелу. *Барыгыз алдында ул «ялтырый», икәүдән-икәү генә калганда «калтырап төшә»!* Р.Гаязетдин. *Адәм баласының рухи дөньясы шыксызланган саен, тышкы кабыгы ялтырый икән.* Н.Гыйматдинова

6) *күч.* Нур чәчү, нурлану. *Ул мәхәббәт төрле җирдә, төрле төстә ялтырый.* М.Гафури. *Ә анда – хаклык кояшы ялтырый, анда – халык игътибары!* Ф.Яхин

7) *күч.* Нинди дә булса хисләр белдереп нурлану, нур чәчү (күзләр тур.). *Әсәрләнүе әле басылмаганга, аңардан ялкын, дәрт бөркелеп тора сыман, күзләре ялтырый, йөзе илһам нуры белән балкыган.* Г.Әпсәләмов. *Сөйләгәндә аның сул кашы сикереп-сикереп китә, күзләре ялтырый.* А.Гыйләҗев

8) *күч.* Ачык йөзле булу, елмаю. *Ул, бик эшлекле икәнен белдерер өчен, ялтырап йөри.* М.Гафури. *Билгеле, эчеңнән карага коелып, тышыңнан ялтырап йөрүләре җиңел эш түгел.* Н.Кәбәш

**Ялтырап алу** Кыска гына вакыт ялтырау; аз гына ялтырау. *Карачкыл күк йөзен телгәләп-телгәләп, еракта яшен ялтырап ала, һавага өлгереп килгән арыш исе – бал катыш яшел башак исе таралган.* М.Мәһдиев

**Ялтырап бетү** Бик нык ялтырау. *Әллә кыставым ошамады, әллә уе-хәсрәте бар идеме: ул таркау гына борылып карады, түш кесәсеннән ялтырап беткән өч тиенлек чыгарды.* А.Гыйләҗев

**Ялтырап китү** Кинәт ялтырау. *Күрәбез: су өстендә ялтырап киткән чабакларны һавадан уктай атылып төшеп эләктереп алалар.* А.Хәсәнов

**Ялтырап кую** Аз гына ялтырау, бер тапкыр яки берникадәр ялтырау. *Түземсезлектән Моратның йөзенә кызыллык бәреп чыкты, күзлек пыялалары ялтырап куйды.* М.Маликова

**Ялтырап тору** Һәрвакыт ялтырау; хәзерге вакытта ялтырау. *Кара айгыр елгада бик әйбәт итеп юылган, каракучкыл булып ялтырап тора иде.* З.Зәйнуллин

**Ялтырап яту** *сөйл. к.* **ялтырап тору**. *Фирүзә төсле күккә, зөбәрҗәт шикелле яшел тауларга, ялтырап яткан суларга карады, дөньяда булмаган бәхет турында уйлана, хыяллана иде.* Гали Рәхим

**Ялтырый башлау** Ялтырарга тотыну. *Кояш чыккач, дөнья нурга күмелә, су өсте көмеш төсле ялтырый башлый.* К.Тәхау

**Ялтырый төшү** Бераз ялтырау; тагын да ныграк ялтырау. *Фәһимә күзендәге яшь элпәсе тагы да ныграк ялтырый төшә.* А.Расих

**ЯЛТЫРБАШ** *и. сөйл.* **1.** Пеләш кеше; чәчсез кеше. *Чөнки татар ирләре-угланнары, чәчләрен пәке белән кырдырып, ялтырбаш булып йөри иде.* Р.Батулла. *– Кем иде ул теге ялтырбаш? – дип, улының каршына йөгереп чыкты.* Кызыл таң

**2.** *с. мәгъ.* Чәчсез, пеләш башлы, такыр башлы. *Ялтырбаш кеше*

**ЯЛТЫ́Р-ЕЛТЫР** *иярт.* **1.** Ялт-йолт ялтырап, җемелдәп тору рәвешен белдерә. *Яшен яшьни: ялтыр-елтыр, ялтыр-елтыр*

**2.** *рәв. мәгъ.* Ялтырап, ялтыравык нурлар уйнатып; җемелдәп. *Ә бабай елмая, күзләре ялтыр-елтыр җемелди.* Н.Дәүли

**3.** *с. мәгъ.* 1) Ялтыравык, җемелдәп торган. *Биек билле, кесәләре алдан уелган чалбарының балаклары ялтыр-елтыр тимерле.* А.Гыйләҗев

2) күч. Ялтырап, очкынланып торган; бик хәрәкәтчән; үткен; хәйләкәр, мут. *Елмаеп утыра әнә, ялтыр-елтыр күзләре белән барыбызны да күзәтеп ---.* Кызыл таң

**ЯЛТЫ́Р-ЕЛТЫР ИТҮ** *ф.* Ялтырау, җемелдәү. *Чыршы уенчыклары ялтыр-елтыр итә*

**ЯЛТЫ́Р-ЕЛТЫР КИЛҮ** *ф. к.* **ялтыр-елтыр итү**. *Рушан машинасын төрле төсләр белән ялтыр-елтыр килеп торган «Жигули»лар рәтенә куйды да базар эченә кереп китәргә ашыкты.* Р.Мирхәйдәров

**ЯЛТЫ́Р-ЙОЛТЫР** *иярт. к.* **ялтыр-елтыр.** *Ала казы калтыр-колтыр, канат очы ялтыр-йолтыр.* Табышмак. *Алар да шул ук мәчеткә баралар, күрерсең, әллә ни кыланып бетәләр: берсе берсе берлә көлешкән булып, ялтыр-йолтыр күзләрен тәрәзәгә әйләндерәләр, әйтерсең аларны монда көтеп торалар.* Г.Исхакый. *Гөл сабакларын сындыра-сындыра, тәрәзә төбенә үк менеп, пыялачының ялтыр-йолтыр маташканын карап тора башлады.* А.Гыйләҗев

**ЯЛТЫ́Р-ЙОЛТЫР ИТҮ** *ф. к.* **ялтыр-елтыр итү**. *Урындык аркасына кунаклап алган рәеш костюмы, тагылган орден-медальләре белән, ут яктысында ялтыр-йолтыр иткәли, гүя соңлавы өчен аны шелтәләргә җыена иде.* Ә.Сафиуллин

**ЯЛТЫ́Р-ЙОЛТЫР КИЛҮ** *ф. к.* **ялтыр-елтыр килү**. *Дивар белән гәүдә арасына кысылган икенче учын көч-хәл белән тартып алып, Шамилнең ташкурчакныкы кебек ялтыр-йолтыр килә торган күзләре тирәсенә куйды.* Р.Рахман

**ЯЛТЫР КОҢГЫЗ** *и. зоол.* Алтын коңгызлар семьялыгыннан агач кәүсәләрендә һәм ботакларда оялый торган ялтыравык, металл төсмерле коңгыз; алтын коңгыз; *русчасы:* **златка**. *Кайберләрен, мәсәлән елга күбәләкләрен, кисмән коңгызларны, гәүдәләре тәңкәләр белән капланган филчек коңгызларны, ялтыр коңгызларны, канатларын «өй кыегы» кебек җыючы төнге һәм башка күбәләкләрне, «йоклату» белән энәгә кадарга кирәк.* Яшь натуралистларга

**ЯЛТЫ́Р-ЯЛТЫР** *иярт. к.* **ялтыр-елтыр**. *Шул арбада чалкан ятып, Инде чана ялга бара... Ялтыр-ялтыр ялтырый, Әлсерәгән: ял сорый...* Ш.Галиев. *Элек өмет – песи күзе – Ялтыр-ялтыр яна иде.* Р.Сөләйманов

**ЯЛТЫ́Р-ЯЛТЫР ИТҮ** *ф. к.* **ялтыр-елтыр итү**. *Ут яктысында алкалары ялтыр-ялтыр иткәли*

**ЯЛТЫ́Р-ЯЛТЫР КИЛҮ** *ф. к.* **ялтыр-елтыр килү**. *Әмма алар гади күркәләр түгел, йолдыз төсле көмеш күркәләр, ялтыр-ялтыр килеп, күзләрне чагылдыралар.* Көмеш кыңгырау

**Я́ЛТ-ЯЛТ** *иярт.* **1.** Яшен кат-кат ялтырап китү, күзгә, пыяла кебек өслектән яктылык чагылып алу рәвешен һ.б.ш. белдерә. *Ялт! Бер тапкыр яшьнәде, тагын бер...* Ялкын

**2.** *рәв.* 1) Тиз-тиз генә; бик тиз, җәһәт-җәһәт. *Чәчәкләрне китап өстендә таратты һәм, кеше-кара комачауламавына куанып, шыгырдавык басма өстенә ялт-ялт менде.* А.Гыйләҗев. *Малай, өстәл янына килеп, компьютерына ялт-ялт баскалый, аннан, җитмеш ике, дип җавап бирә.* Ф.Җамалетдинова

2) Анда-монда каранып. *Рәхимсез йөртәдер күзләрне ялт-ялт.* Г.Камал

**ЯЛТ-ЯЛТ ИТҮ** *ф.* Җемелдәү, ялтырау. *Кара каз как-как итә, канат очы ялт-ялт итә.* Табышмак. *Бармак очы кадәр генә ут ара-тирә ялт-ялт итеп китә...* Ә.Еники

**ЯЛЧЫ** *и.* **1.** 1) Байларга ялланып эшләүче хезмәтче. *Кара ялчы булып иңбашыңа урак салып йөрү түгел, менә бу басуларның хуҗасы булуыңны телим мин.* М.Хәсәнов. *Хуҗасының сүзен әмер сыман кабул итте бугай, янда гына торган ялчы Госсам, кисәк кубып, абзар тактасына каккан чылбырга ябырылды.* В.Имамов // Хуҗалык эшләрендә ярдәм итүче, хезмәтче. *Ләкин ялчылар томмый, үз көче, балаларының көче белән көрәйгән хуҗалык иде ул.* Р.Батулла. *Ә кызын, ялчы итеп, хуҗалыктагы иң пычрак, иң әшәке эшләрне башкарырга мәҗбүр итә.* Н.Сәйяр

2) *күч.* Башкалар кушканны башкаручы кеше. *Аннан җыйган әйберләрне кинәнә-кинәнә сатасы була инде сиңа, апа бәгырькәем. Бибисара – Фәнзиләнең ялчысы!* Н.Гыйматдинова

3) *күч.* Дәрәҗәле кешеләр кушканны үти торган кеше; сатылган кеше, сатлык җан, ялагай, тәлинкә тотучы. *Ә түрәләрнең боерыгын ялчылар төгәл үти.* Н.Гыйматдинова. *Аптул Хөснетдиныч гомере буе, хакыйкать эзләүче маскасын киеп, хакимиятнең иң тугры ялчысы буларак иҗат итте, беркемнең дә тикмәгә депутатлыкта йөртмиләр, агай-эне.* Р.Зарипов

4) *күч.* Ирексез; башкаларга бәйле кеше. *Гомерлек ялчы син, и халкым, Азатлык килерме сиңа бер?..* Р.Әхмәтҗанов. *Халык, гражданнар һәрдаим дәүләтнең ялчысы булып килделәр.* Н.Шәрифуллин

5) *күч.* Кем яки нәрсә хакына хезмәт итүче, кемнәрнеңдер мәнфәгатьләрен яклаучы; нинди дә булса юнәлеш, караш тарафдары булып, бик күп вакытын, хезмәтен һ.б. шуңа багышлаган кеше. *Минем мәзин бабайны кара елларда, дин ялчысы дип гаепләп, атырга кушканнар.* Н.Гыйматдинова. *Кызганыч, күпме вакытлар хакыйкать ялчысы булып йөрүдә үтелгән.* Ф.Яхин

**2.** *с. мәгъ.* 1) Ялланып эшли торган. *Тай саклаучы ялчы малайлар Тулган айга карап моңайганда, Тукай моңы белән моңайган.* М.Шабаев. *Йокысыз төннән соң Миңлебай, аш өендәге ялчы хатыннан күмәч, сөт алып ашады да, башка вакыттагы кебек Муллагали белән саубуллашып-нитеп тормастан, тиз генә атын иярләде һәм, атланып, капкадан чыгып та китте.* Н.Яһудин

2) *сөйл.* Хакимият вәкилләренең, житәкчеләрнең, байларның ярдәмчеләре булган; үз мәнфәгатьләре өчен шуларга сатылып, ялагайланып, алар кушканның барысын да үтәгән. *Аның ялчы малайлары минем башымны идерә алмады, шуңа Фәлинов-Фәләновлар юк-барга да каныга, ә менә сине нигә яратмыйлар?* Н.Гыйматдинова

**ЯЛЧЫГУ** *ф. диал. к.* **ялыгу**. *Урман киссәң эштә ялчыгуда: «Урынын тапты, – дияр, – ул да – кеше!»* Ф.Яхин. *Өстәвенә, урак урып, ялчыгып, төшке, кичке ашка туктаган авылдашларының сугыш михнәтләреннән, югалту ачыларыннан кырыслана башлаган күңелләрен тальян моңнары белән дә эретә ул.* Туганайлар

**Ялчыга бару** *к.* **ялыга бару**. *Ялчыга баруымны сиздем*

**Ялчыга башлау** *к.* **ялыга башлау**. *– Картаям бугай, тиз ялчыга башладым, – ди ул беркөнне.* М.Вәлиев

**Ялчыга төшү** *к.* **ялыга төшү**. *Бабай ялчыга төште*

**Ялчыгып бетү** *к.* **ялыгып бетү**. *Ялчыгып бетсә дә сиздерми*

**ЯЛЧЫЛЫК** *и.* Ялчы булу, ялчы вазифасы. *Ай ярым вакыт үтүгә, Миңлебай --- авылының иң комсыз кешесенә ялчылыкка килде.* З.Зәйнуллин. *Ялчылыкта йөри ничәнче ел, Этҗан булды, булды йомычка!* Ф.Яхин

**ЯЛЧЫЛЫ́К ИТҮ** ф. 1) Ялчы булып эшләү; ялчы булып хезмәт итү; хуҗа кушканнарны эшләү. *Мин тегермән тотучы бер байда ялчылык итәм.* М.Галәү. *Ялчылык итә ул Гадәте буенча Черегән бер немец баена.* Ә.Маликов

2) *күч.* Ялагайлану; тәлинкә тоту. *Ялчылык итүчеләр күбәйде*

**ЯЛЫГУ** *ф.* 1) Ару, талчыгу, хәлдән таю. *Урманнан да күңеле кайта башлаган, ахры – бу шомлы дөньядан Хәлим тәмам ялыкты.* Г.Гыйльманов

2) Туюы; күңел кайту, дәвам итәсе килмәү, көрәсе килмәү. *Дөресен әйткәндә, Бибинур алардан ялыгырга да өлгерде.* А.Гыйләҗев. *Чәйнәп каптырганны гына йотарга өйрәнгән ялкау укучы аңардан бик тиз ялыга.* А.Тимергалин

**Ялыга бару** Торган саен ныграк ялыгу. *Эшемнән ялыга барам*

**Ялыга башлау** Ялыгу билгеләре күренү, сизелү. *Озакка сузылган өметсез авыруның бик күңелсез бер ягы бар: авыручы үзе дә, аны караучылар да акрынлап ялыга башлыйлар.* Ә.Еники. *Кунаклар ялыга башладылар, әмма сораулар һаман тукталмый иде.* Г.Мөхәммәдова

**Ялыга төшү** Бераз ялыгу; тагын да ныграк ялыгу. *Ниһаять, җырлый-җырлый ялыга төштек бугай, дәртле тавышлар, кичке гөрләвекләрдәй, әкрен-әкрен үз ярларына кайта башлады.* Ш.Маннур

**Ялыгып бетү** Тәмам ялыгу. *Кешеләр дә, кунаклар да ялыгып бетте – башларга кирәк.* Н.Фәттах. *Курмашевны шофёр асфальтта көтеп тора иде. Ул пассажирын көтә-көтә ялыгып беткән иде, ахры, Курмашевтан: «Туйганчы озон суладыгызмы?» – дип сорады.* М.Зарипов

**Ялыгып китү** Бераз ялыгу. *Утырып эчә-эчә ялыгып китсә, Мөнәвәр абзагыз ул якны да алдан ук күздә тоткан: алып чыккан мендәр, шул мендәргә янтаеп барып төшәр.* Ф.Хөсни. *Утыра торгач, Шаһи барлык уйларын да уйлап бетте, ялыгып та китте.* З.Мурсиев

**Ялыгып кую** Сирәк кенә, кайвакыт ялыгу. *Фатихның кунаклары көнләшү хисләре уятса да, Габдулла килешергә мәҗбүр: Фатих – авыру, бәлки, кунаклардан ул алҗып, ялыгып та куядыр, ләкин нәкъ менә алар аша ул тормыш белән һәрдаим элемтәдә тора.* Р.Вәлиев

**ЯЛЫ́К-ЙОЛЫК** *иярт.* **1.** Ялтырап, җемелдәп тору рәвешен белдерә. *Йолдызлар ялык-йолык*

**2.** *с. мәгъ.* Җемелдәгән, төрле төсләргә кергән. *Безгә үзе җигеп йөри торган, янына килсәң котың очардай, су анасыныкыдай тузгыган ялык-йолык кара ялләры тезеннән түбән алмачуар айгырын күрсәтә.* А.Хәсәнов. *Ялык-йолык погоннар*

**3.** *рәв. мәгъ.* Төрле төсләргә кереп, ялтырап, җемелдәп, күзне камаштырып. *Арбада зур-зур төеннәр һәм ялык-йолык ялтырап торган аккордеон.* Ф.Баттал

**ЯЛЫ́К-ЙОЛЫК ИТҮ** *ф.* Ялтырап яки төрле төсләргә кереп җемелдәп тору. *Сызылып ай яктысы төшкән, итекләрем ялык-йолык итеп яталар.*

Ф.Хөсни. *Сәгать ала икән – алтын булсын, йөзек ала икән – кыйммәтле ташы ялык-йолык итеп торсын.* Ф.Яруллин

**ЯЛЫ́К-ЙОЛЫК КИЛҮ** *ф. к.* **ялык-йолык итү**. *Вакытында ашатмый-эчертми, өсте ялык-йолык килеп торырлык булганчы ябагадан чистартмый, алашабызны җәен тарантаска, кышын кошевой чанага җикмәдем.* А.Хәсәнов. *Бал-маскарад алдыннан Эльза ялык-йолык килеп торган «Нокиа»сын күтәреп, мәктәпкә очып килеп керде: – Гари-и-иф!* А.Гыймадиев

**ЯЛЫКТЫРГЫЧ** *с.* 1) Арыта, алҗыта, хәлне ала торган. *Авыр, ялыктыргыч, әмма кызык, мавыктыргыч яклары да бар армия хезмәтенең.* С.Шәрипов. *Аларның эше авыр һәм ялыктыргыч...* Н.Яһүдин

2) Эчпошыргыч, туйдыргыч. *Ялыктыргыч кышкы кичләрдә электрны сәгатьләп кенә бирә башлаганга, туңмай шәме яктысында Азат озын-озын шигырьләр ятлый, аларны, таләпчән фрау каршысына басып, үзе дә әсәрләнеп, ләззәт алып сөйли – сөйләм телен чарлый.* А.Тимергалин. *Мич артында чикерткә үзенең ялыктыргыч озын көен сузып җибәрде.* Д.Бүләков

**ЯЛЫКТЫРУ** *ф. йөкл. юн. к.* **ялыгу**. *Юл ялыктыргандыр, хәзер ял итәрсез, ашарсыз, тәмле ширбәт белән сыйланырсыз.* А.Гадел. *– Авыл да, матур җыр кебек, ялыктырмый бит, – диде.* А.Гыйләҗев

**Ялыктыра бару** Акрынлап ялыктыру; ялыктыра башлау. *Көчле музыка ялыктыра баруын сизсәм дә, чыгып китәргә кыенсындым.* Р.Вәлиев

**Ялыктыра башлау** Ялыктырырга тотыну. *Шулай да телсез кеше кебек, чылбырга бәйләп куелган кол кебек, бер урыннан кузгалмыйча, тукталмыйча ишеп бару аны озакламый ялыктыра башлады.* Н.Фәттах. *Сораулар ялыктыра башлагач, Фаил абый үзгәреш кертергә теләде.* К.Кәримов

**Ялыктыра төшү** Беркадәр ялыктыру; тагын да ялыктыру. *Кичәге һәм бүгенге тарих сәхифәләрендә казыну Клара Сентны ялыктыра төште булса кирәк, тиздән ул сүз сөрешен бөтенләй икенче тарафка борып җибәрде ---.* Рав.Вәли. *Озынга сузылган тамаша ялыктыра да төште.* А.Юнысова

**Ялыктырып бетерү** Тәмам, бик нык ялыктыру. *Мондый сүзләр, йөрисен йөреп, тыңланып, колакларны ялыктырып бетергәч кенә, Гәүһәрнең үзенә дә килеп ирештеләр.* Х.Ширмән. *«Сезнең хөрмәткә бер кыска гына шигыремне укыйм», – дип, сәхнәгә менгән Шаһбазны куып төшерерлек түгел иде: укый да укый, укый да укый, халыкны тәмам ялыктырып бетерә торган иде...* Х.Ибраһим

**Ялыктырып җибәрү** Бераз ялыктыру. *Картиналар язу ялыктырып җибәрсә, нинди дә булса кул эшенә тотынам.* Сөембикә. *Йөргән кызым белән талашкан вакыт иде, эстрада тормышы да ничектер ялыктырып җибәргән кебек тоелды.* Акчарлак

**Ялыктырып килү** Күптәннән бирле, эзлекле рәвештә, даими ялыктыру. *Бу эшләр аны ялыктырып килә иде инде*

**Ялыктырып тору** Сөйләү моментында ялыктыру; даими ялыктыру. *Озак сөйләп, халыкны ялыктырып тормыйк.* Кызыл таң

**ЯЛЫНА́-ЯЛВАРА** *рәв. к.* **ялынып-ялварып**. *Әмир әнә шул рәвешчә, ялына-ялвара, Бүздәктәге бөтен оешма ишекләрен, барча кабинетларны айкап чыкты – аның сүзенә колак салучы түрә табылмады.* В.Имамов. *Аннары Кашка тәкә янына килеп ялына-ялвара тез чүккән.* Г.Гыйльманов

**ЯЛЫНДЫРУ** *ф. йөкл. юн. к.* **ялыну**. *Хатларыңны ялындырып кына язма.* Н.Нәҗми. *Иллә дә шул гадәтеңне яратмыйм, Зөлхый, бурычка барыбер бирәсең бит инде, ник шулкадәр ялындырасың.* И.Юзеев

**Ялындыра башлау** Ялындырырга тотыну. *Сөембикә тора-бара аны ялындыра башлады, рәхәтләнеп назланды, вакыт тапмаганга салынып, юри үртәде, очрашкач, алдына тезләндерде, киръәксә – табанын ялатты.* Ф.Садриев. *Юкса ялындыра башласаң, бу чибәр нәрсә, аны калдырып, бүтән белән китәргә дә күп сорамас.* Р.Кәрами

**Ялындыра төшү** Бераз ялындыру; тагын да ялындыру

**Ялындырып йөрү** Даими, гел ялындыру; озак вакыт дәвамында ялындыру. *Өйләнешеп яши башлагач, сорадым үзеннән: «Нәрсә инде ялындырып йөргән булдың?»* Т.Миңнуллин

**Ялындырып тору** Һәрвакыт, даими ялындыру; сөйләү моментында ялындыру. *Ихсан ялындырып тормады, бара-барышка ук киемнәрен салып, суга ташланды.* Ф.Яруллин. *Нәфисә ялындырып тормады, хуш исле печән түшәлгән арбага ялт итеп менеп тә утырды.* Г.Гыйльманов

**Ялындырып утыру** *сөйл. к.* **ялындырып тору**. *Шунда, кухня ягыннан кереп килгән Әсма апа, ике уйлап тормастан, туп-туры үзенең ире янәшәсенә килеп басты: – Ялындырып утыра торган чак түгел, әтисе.* Р.Мөхәммәдиев

**ЯЛЫНУ** *ф.* Озаклап үтенү; үтенеп, ялварып сорау. *– Мин бит үзем өчен генә сорыйм... беркемгә дә әйтмәм, Диләфрүз, – дип ялынды Чибәркәева.* Г.Әпсәләмов. *Иптәш булырсың, бер генә әйләнеп килик инде, дип ялына Шакир.* Л.Лерон

**Ялына башлау** Ялынырга тотыну. *Рөстәм, һичьюгы болары булса да елый, ялына башлар, дип көткән иде, тик малайлар тарафыннан шылт иткән дә тавыш ишетелмәде.* В.Имамов

**Ялына бирү** Бернигә карамый ялынуын дәвам итү. *Кыз әнисенә ялына бирде*

**Ялына килү** Күпмедер вакыт дәвамында ялыну. *Озатып баручы солдаттан юл буе ялына килгән иде.* Р.Рахман

**Ялына тору** Озак вакыт дәвамында ялыну; күп ялыну; һаман ялыну. *Ялына торгач, берсеннән-берсе кыска дүрт хикәя язып килде.* И.Юзеев. *Ләкин Әбүзәр, ялына торгач, квартирантларны тәки күндерде бит.* А.Тимергалин

**Ялына төшү** Бераз ялыну; тагын да күбрәк ялыну. *– Җибәр инде, – диде Маруся, ялына төшеп, – күреп торасың ич, Матвей Савельич.* А.Расих

**Ялынып бетү** Бик нык ялыну; озак вакыт дәвамында ялыну. *– Баланы чыгарыгыз инде, – дип ялынып беттем.* Кызыл таң

**Ялынып йөрү** Даими ялыну; озак вакыт дәвамында ялыну. *Авызыңа салган сары майны хәзер йота белмәсәң, соңыннан үзең телләреңне салындырып ялынып йөрерсең әле.* Г.Камал

**Ялынып калу** Билгеле бер вакытка, хәлгә, вакыйгага кадәр ялынырга өлгерү. *Хәзер дусларга шалтыратып: кирәген кисәтеп, җаваплысыннан үтенеп, зуррагыннан ялынып калырга кирәк.* А.Гыйләҗев

**Ялынып карау** Булу-булмавын сынау өчен ялыну. *– Я инде, Хәбибрахман абзый, – дип ялынып карады.* А.Гыйләҗев

**Ялынып тору** Әледән-әле, еш ялыну; хәзер ялыну. *Берничә ел элек кенә кунакханәдә администратордан урын сорап ялынып торганын ишеттем мин моның.* Н.Гыйматдинова. *Берәр җиргә барасың булса, иртәнге биштә нәрәткә*

*барасың, хәер өмет иткән теләнчедәй, ишек төбендә басып, рәискә ялынып торасың.* Н.Көбәш

**Ялынып утыру** *сөйл. к.* **ялынып тору**. *Мулланурның холкын белгән Һаҗирә вакыт уздырып ялынып утырасы итмәде, авылның бөтен ирләренә әйтеп бетермәгәндер әле дип, урамның теге ягында яшәүче Хәмиткә барырга уйлады.* Г.Бәйрәмова

**ЯЛЫНУЛЫ** *с.* Ялыну катыш; үтенүне, ялынуны белдергән. *Бераз тынып торган радио тагын кыштырдады, һәм ханым да радистның курку катыш ялынулы тавышын ишетте: – Дүртенче вагонга!..* А.Гыйләҗев. *Әтисе, ялынулы һәм кызганыч тавыш белән урядникка нәрсәләрдер сөйли, аңарданниләрдер үтенә.* Н.Яһудин

**ЯЛЫНУ́-ЯЛВАРУ** ф. **1.** Озак, каткат ялвару, үтенү, ялыну. *Ялындыялварды, тик теләгән нәтиҗә булмады*

**2.** *и. мәгъ.* Үтенеп сорау; ялвару сүзләре. *Ялыну-ялварулар күкләргә ишетелдеме, көткән сәгате суктымы – нәни җан иясенең яралуы мәгълүм булды.* Р.Муллланурова. *Бу ялыну-ялваруларны укыйм да аларның тизрәк яңа йортларга күченүен телим.* Идел

**Ялына-ялвара башлау** Ялынырга-ялварырга керешү. *– Миңа да өйрәтчәле, мин дә барып алыйм әле шуны, – дип, Төлкегә ялына-ялвара башлады, ди.* Әкият

**Ялына-ялвара тору** Озак вакыт дәвамында ялыну-ялвару. *Ялына-ялвара торгач, төрек егете, сумкамны кулымнан тартып алып, үлчәми-нитми транспортёрга ташлый һәм миңа талон тоттыра.* Р.Ибраһимов

**ЯЛЫНЫП-ЯЛВАРЫП** *рәв.* Ялынып һәм ялварып, үгетләп, бик нык сорап. *Ялынып-ялварып чакырып кайтардың да аягымнан юл тузаны төшмәс борын миңа җикеренәсеңме?* А.Гыйләҗев. *Бүген төндә Ходай Тәгалә минем теләгемне ишеткән, ялынып-ялварып укыган догаларымны кабул иткән...* Г.Гыйльманов

**ЯЛЫНЫЧ** *и.* Үтенеч; ялварулы, түбәнчелекле мөрәҗәгать. *– Ачуланма, Ислам, – диде ул, күрәләтә бер ялыныч белән.* Н.Фәттах

◊ **Ялыныч төшү** Кемнең дә булса ярдәменә мохтаҗ булу. *Инде кунак кызына ялыныч төште.* Ф.Тарханова. *– Сиңа ялыныч төшәр дип кем уйлаган? – диде энесе коры гына, ишек ябылу белән.* В.Имамов

**ЯЛЫНЫЧЛЫ** *с. к.* **ялынулы**. *Ухсиүкси торып утырды да үзенең баш очында аякларын аерып басып торган коточкыч кешегә ялынычлы күзләрен текәде.* Н.Фәттах. *Флүрәсенең ялынычлы, моңлы күз карашы көзгедәге шәүлә төсле генә чагылып үтте.* Р.Мулланурова

**ЯМ** *и. тар.* 1) XIII гасыр башында Алтын Урдада барлыкка килгән, соңрак татар ханлыкларында гамәлдә булган почта элемтәсе челтәренең атлар алыштыра торган станциясе. *Һәр 30 чакрым арада бер ям (ыстанса) булырга, шул ямда юлчыларга ашау-эчү, ятак, ат алмаштыру кебек мөһим шартлар булдырырга.* Р.Батулла

2) XIII–XVIII гасырларда Россия дәүләтендә халкы ямчылык хезмәтен үтәгән почта трактындагы торак пункт. *Татарстанның төньягы буйлап сузылган Чуваш юлы Удмуртиягә киткән (юл дип Казан дәүләте чорында ям юлын да, шулай ук зур административ өлкәне дә атаганнар).* Р.Әхмәтьянов. *«Ям» тамыры юл читендәге торак урыннарны – станцияләрне белдерә, атлы кешеләр аларда төн куну, тамак ялгау, атларын алыштыру өчен туктала торган булганнар.* Я.Шәфыйков

3) XVIII–XIX гасырларда Россия дәүләтендә атлар алыштыра торган почта станциясе. *Алар ул юлларны карап торарга, ат-арбалар булдырып, ям хезмәтен оештырырга, ям станцияләрен төзергә тиеш булалар.* Л.Хәмидуллин

**ЯМАН** с. **1.** 1) Начар, юньсез, рәтсез (кеше тур.). *Адәмнәр яман бәндәләргә әверелеп бетте, ди.* Р.Батулла. *Тик шуны аңла: син мине һаман да явыз, яман кеше итеп күрергә тырыштың.* Х.Ибраһим

2) Усал, мәкерле, эчкерле, явыз (фикер һ.б.ш. тур.). *Әгәр дә алар яман ният белән йөриләр икән, без сезне куркыныччтан берничек тә аралап кала алмаячакбыз.* Р.Вәлиев. *Әмма Мирвәлинең эчендә яман уй һәм ният оеткысы калганлыгын белеп өлгерә алмады.* Ф.Яхин

3) Куркыныч. *Ә калганы инде, тәмам ватып, шабыр тиргә батырып уята торган саташулы яман төш кебек кенә булды.* М.Хәсәнов

4) Йогышлы; инфекция эләгү аркасында барлыкка килә торган (авыру тур.). *Мин шуннан берничә ай элек кенә, бераз «гүләйт итеп», яман чир эләктердем.* Р.Мостафин

5) Дәвалап булмый торган; тормыш өчен куркыныч булган; үлемгә китерү ихтималы булган. *Яман чир аны бер ай эчендә коры сөяккә калдырды, бернинди врач-табиблар ярдәм итә алмады.* Р.Мирхәйдәров. *Инде ике-өч ай буена тамагыннан бер ризык та үтми, яман шеш дигәне эчтән талый, хәзер бар көннәре түшәк өстендә уза икән...* В.Имамов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Тискәре яктан, негатив рәвештә; начар дип, хурлап; начар итеп. *Авылның дорфа кешеләре дә аларга авыр сүз әйтми, алар турында яман сөйләми.* Р.Батулла. *Син ничек аның турында яман уйлый алдың?!* В.Имамов

2) *сөйл.* Бик, үтә, ифрат. *Без моның шулай икәнен мишәр егетенең яман каты кычкырып кызуларга тырышуыннан аңыштык.* К.Миңлебаев. *– Кызык, яман кызык, – диде Ямгырчы би, чын-чынлап кызыксынгандай итенеп.* Н.Фәттах

**3.** *хәб. функ.* Кыен, читен, начар. *Температурасы да, бәлки, төшәр иде, телдән язган, бичаракай. Шунысы бик яман.* Ф.Яруллин. *Мондый вакытта юлда булуың бик яман.* Р.Батулла

◊ **Яман күз** 1) Каты күзле кеше сокланып, кызыгып караса, күз тия, дип ышанылган, әшәке, начар күз. *Бу дога сүзенең яман күз тиюдән укыла торган дога икәнен генә белә Зәкәрия карт...* Г.Гыйльманов. *Әллә яман күз тиде инде шуңа?* Ялкын; 2) Башка кешеләргә яки аларның әйберләренә көнләшеп, яратмыйча, начар уйлар белән карау гадәте. *Башкаларның малына, намусына яман күз белән карау ярамый.* Сөембикә; 3) Кеше әйберенә кызыга торган кеше, карак; кемгә яки нәрсәгә дә булса кызыгып, начарлык кыла торган кеше. *Ходай инде яман күздән, хәвеф-хәтәрдән генә үзе сакласын.* Г.Камал. *И Раббым, ошбу сабыеңны бәхеткәйләреннән мәхрүм итә күрмә, ятимлек хәсрәтләрен берүк бирә күрмә, яман күзләрдән Үзең сакла!* Г.Галиева. **Яман тел** 1) Гайбәтче. *Шуның өстенә, әле яман телләрне, аларның «бер-бер гөнаһысы бардыр...» дип гөман кылуларын кая куясың.* Р.Мөхәммәдиев. *Кыз бала яшәгән шушы өйне таң атканчы яман күзләрдән, яман телләрдән саклап карап утырыйм...* Т.Гарипова; 2) Әшәке, оятсыз сүзләр сөйли торган кеше, сүгенә торган кеше. *Яман тел пычактан хәтәр яралый.* А.Гыйләҗев; 3) Начар сүз; гайбәт; әшәке сүз. *Аның турында яман тел әйтергә берәүнең дә авызы ачылмады.* Г.Ибраһимов. **Яман телле** Тупас, дорфа сөйләшә торган. *Ашамый-эчми, ормый-сукмый,*

*яман телле, каты сүзле түгел.* Т.Гыйззәт. **Яман телләнү** 1) Гайбәт сөйләү; 2) Оятсыз сүзләр сөйләү; сүгү, сүгенү. *Бүген ул да яман телләнә, ди.* Г.Ибраһимов. *Ибрай абзар буйлап узып барганда [атка] чыбык белән сугып киткәч, Шәйхаттар бабай яман телләнде.* Г.Гобәй. **Яман телләргә азык булу** *к.* **яман телләргә эләгү**. *Кызының, яман телләргә азык булып, аты-чабы чыкмагае дип, гел сагаеп килгән ана мондый хат алышуны яхшы күрмәде.* Г.Минский. **Яман телләргә эләгү** Гайбәте таралу, начар даны чыгу. *Хәзер яман телләргә эләгерсең.* Г.Ибраһимов. *Яман телләргә эләгеп атың-чатың чыга-нитә калса...* М.Хәсәнов. **Яман телләргә яманаты керү (чыгу)** *к.* **яман телләргә эләгү**. *Берсе шушы Гафар абый, икенчесе аның яшьтәш дусты Баһау абый, өченчесе Гөлбәдрия дигән бик сөйкемле генә, яман телләргә яманаты кермәгән бик инсафлы гына бер кыз.* Ш.Маннур. **Яман чир** Начар гадәт; начар сыйфат. *Нишләп әле «Мин – сиңа, син – миңа!» дигән яман чир тормышыбызның мәгънәсенә әверелеп бара?* М.Хәсәнов. *Нәселдән нәселгә күчеп килә торган яман чир ул комсызлык.* Аманулла. **Яман юлга керү (басу)** Бозыклык юлына керү, бозылу. *Ә бит Чәчкәгә яман юлга кереп китәргә күп калмаган иде.* Ф.Яруллин. **Яман юлда йөрү** *к.* **яман юлга керү (басу)**. *«Тәртипле йөр, улым, йөзебезгә кызыллык китермә, яман юлда йөрмә», – дип үгетләп чыгарып җибәрә.* Р.Батулла

**ЯМАНАТ** *и.* 1) Начар дан, пычранган исем. *Гомер юлыңны тәмамлап килгәндә, чал сакалыңа «карак» дигән яманат ябыштырсыннар әле...* А.Гыйләҗев. *Халык үзенә «сәрхуш» дигән яманатны тагып өлгергән дә бугай...* В.Имамов

2) Гайбәт, кеше турында начар хәбәр, сүз. *Наратлыкта бозык үрчи, дигән яманат күршеләргә ишетелмәсен!* Н.Гыйматдинова

◊ **Яманатка калдыру** Оятка калдыру, оятлы итү; начар дан таралуга сәбәпче булу; башкалар турында начар уйларга сәбәп бирү. *Шуңа күрә бу егетләр, үзләре дә кызларны яманатка калдырудан бик сакланып, караңгы төшкәч кенә киләләр һәм рөхсәт белән керәләр.* Н.Исәнбәт. **Яманатка калу** Начар даны таралу; хур булу; яманат күтәрү, яман даны таралу. *Яманатка калуыңны сизмәссең дә.* Ш.Маннур. **Яманат тагу** Кешегә яман исем тагу, гайбәтен тарату. *Теге чакта ул, күпме генә тырышса да, Аппак белән Тотышка «уйнашчы» дигән яманат тага алмады.* Н.Фәттах. *Яманат таксалар да, Яман күздән Ходай сакласын.* Туганайлар. **Яманатын сату** 1) Кем турында булса да начар сөйләү, гайбәт тарату. *Миннән бәхил бул, синең кызыңның яманатын саттым.* Г.Исхакый; 2) Берәр нәрсә турында начар дип сөйләү, яманлау. *Күрмәдеңмени, безнең яңа продукциянең яманатын сата, үлгән гармунны күккә күтәрә.* И.Юзеев. **Яманаты чыгу** Кем турында булса да гайбәт таралу, кешенең начар даны таралу; кем яки нәрсә турында начар сүз чыгу. *Гомер буена ялгышып та ник бер яманатлары чыксын...* Г.Галиева. *Язмышы булгандыр инде, яманаты чыккан өйгә килен булып төшүен Зәкия абайламый да кала.* З.Мурсиев

**ЯМАНАТЛЫ** *с.* Яманаты чыккан. *Яманатлы була-була кешегә яхшылык эшлисең.* Ш.Галиев. *– Минә бу лимоннарны Җәмиләттәй малае китерде, – диде, чөнки Фатихны яманатлы итеп күрсәтәсе килмәде.* Ф.Яруллин

**ЯМАНЛА́У** *ф.* Хурлау, начар дип сөйләү. *Үзеннән алда үткәннәрне яманлап, һәр яңа җитәкче үз бәясен арттыра.* А.Гыйләҗев. *Апасы белеп яманлый: алар нәселе кызу канлы, дуамал.* Н.Гыйматдинова

**Яманлап алу** Аз гына яманлау; берара яманлау. *Гамил иске торбалар биргән хуҗалык мөдирен яманлап алды.* А.Тимергалин

**Яманлап җибәрү** Бераз яманлау. *Бер-берсен яманлап җибәрергә дә күп сорамыйлар*

**Яманлап йөрү** Гел, даими яманлау; озак вакыт дәвамында яманлау. *– Гел яманлап йөри бу Илһамия, – диде өстәл җыештырып маташкан Фатихәттәй.* Г.Әпсәләмов

**Яманлап килү** Күптәннән, әллә кайчаннан бирле яманлау. *Күршесен күптәннән яманлап килә иде инде ул.* Кызыл таң

**Яманлап кую** Бер тапкыр яманлау. *Үзсүзле, тәкәббер шәһәр кызын күңеленнән ул хәтта яманлап куйды.* Н.Фәттах

**Яманлап тору** Әледән-әле, еш яманлау; хәзер яманлау. *Юньсез Альберт, күзең йомсаң, күз алдында сиңа ошаган кызны яманлап торадыр кебек.* Р.Батулла

**Яманлап утыру** *сөйл. к.* **яманлап тору**. *– Ни җитмәгән тагын сиңа? Авылны яманлап утырасың, – диде ул, пышылдап кына.* А.Хәлим

**Яманлый башлау** Яманларга керешү. *Шуннан соң инде ул Нәфисәне туктаусыз яманлый башлады.* А.Шамов

**Яманлый бирү** Бернигә дә карамый яманлау; яманлавын дәвам итү. *Берәүләр Радикны күккә чөеп мактый, икенчеләре, усалланып, яманлый бирә.* Өмет

**Яманлый килү** *к.* **яманлап килү**. *Хөкүмәтне яманлый килү*

**Яманлый тору** Даими, гел яманлау; озак вакыт дәвамында яманлау. *Кыз юктан да Кәримәне яманлый торды.* Ф.Яхин

**Яманлый төшү** Беркадәр яманлау; тагын да яманлау. *Күршеләрен яманлый төшеп сөйләвен дәвам итте.* Идел

**ЯМАНЛЫК** *и.* 1) Кеше характерындагы сыйфат буларак усаллык, начарлык, әшәкелек. *Әмма яманлык канына бер сеңгән кеше шуннан тәки мантый алмый булса кирәк.* В.Нуруллин

2) Явыз ният, мәкер. *Аның ачуланасы да бик килә, белергә теләве дә көчле, яманлык белән миннән сүз алырга мөмкин түгеллеген яхшы белгәнгә, ул җайлап кына мине юмаларга, үгетләргә тотынды.* А.Гыйләҗев

3) Начар гамәл, кешегә эшләнгән явызлык. *Яманлык күренеп йөрми, ул астыртын эшләнә.* Г.Тарханова. *Сездән көт яхшылык, алырсың яманлык.* Д.Салихов

**ЯМАНСУ** *с.* **1.** 1) Сагышланган, күңелсезләнгән. *Кычкырып җырламас идем – Бик ямансу чакларым...* Ә.Салах. *Алар фани дөньяның ыгы-зыгылы бер төшендә синең тирәдән югалып торалар да, көтмәгәндә берән-сәрән очрап, көндәлек тормышыңның ямансу халәтенә сөенеч өстәп куялар.* К.Кәримов

2) Күңелгә борчу сала торган, сагышландыра торган, күңелсез, эчпошыргыч. *Әйе, нәкъ менә Илүсә китеп барганнан соң, ямансу кичләрнең берсендә Мортаза әнисенең сандыгын актарып карыйсы итте.* М.Маликова. *Минә бүген дә, көзге ямансу боек көнгә, ямьсез соры болытлардан тамып торган вак тамчыларга карамыйча, ыңгырашып искән, күңелләрне өшетә торган җилгә колак салмыйча, ул зиратта йөри иде.* Л.Шәех

**2.** *рәв. мәгъ.* Күңелсез, борчылып, сагыш белән. *Без бөтен Кояшлыга ике бөртек кенә калсак та, бу җәебез алай ямансу үтмәде.* Г.Мөхәммәтшин. *Өйләнмәскә ант иткән кеше кебек, бигрәкләр дә ямансу итеп әйтә.* Г.Гыйльманов

**3.** *хәб. функ.* Күңелсез булу; сагыну, ямансулау турында. *Бергә торган чаклар рәхәт иде. Аерылышу бигрәк ямансу.* Җыр. *Син киттең. Миңа ямансу*

**ЯМАНСУЛАТУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **ямансулау**. *Авылдан чыгып китеп зимагурлыкта йөргәннәр дә оныта алмыйлар Галия тавын – чит җирләрдә каңгырып йөргән бәхетсезләрнең төшенә кереп, ул аларны ямансулата, күңелләрен нечкәртә.* Т.Мөбарәков. *Аның белән аерылышу беркемне дә әллә ни ямансулатмады.* С.Шәрипов

2) *з.-сыз* Ямансу булып китү, сагышландыру, моңландыру. *«Шөкер, кеше арасында ким-хур итмичә, җиренә җиткереп, җеназасын укытып җирләдек, – ди дә, моңаеп, – тик ямансулата, сагындыра», – дип өстәп куя.* Р.Камалетдинова

**Ямансулата бару** Торган саен ныграк ямансулату

**Ямансулата башлау** Ямансулатырга тотыну. *Үзем генә калгач ямансулата башлый.* Р.Вәлиева

**Ямансулата төшү** Бераз ямансулату; тагын да ямансулату. *Үз күзләрем белән күргәч, бигрәк тә ямансулата төште.* Кызыл таң

**Ямансулатып тору** Әледән-әле, еш ямансулату; хәзер ямансулату. *Ә иң яманы – нәрсәдер эчне пошырып, ямансулатып тора.* Х.Камалов

**ЯМАНСУЛА́У** *ф.* Сагышлану, сагышка бирелү, күңелсезләнү, уйга бату. *Башта алар аналарыннан аерылганга бик ямансуладылар, бик күңелсезләнделәр.* Гали Рәхим. *Рәйхан да, Шәүкәт вафат булгач, аны җирләгәч, бик ямансулады, йөрәге сулкылдады.* Д.Каюмова

**Ямансулап алу** Бераз ямансулау; берара ямансулау. *Күктә йөзгән каурый болытларны төрле җанварларга охшатып, бер көлеп, бер ямансулап алдылар.* Г.Гыйльманов. *Кайгым булса, ямансулап алсам, Таяныч эзләп сиңа килəм мин.* Ф.Солтан

**Ямансулап бетү** Тәмам, бик нык ямансулау. *– Джунглида синнән башка ямансулап беттек, – һәм Баһира, йөгереп килеп, Мауглиның ялан аякларына сырпаланды.* Р.Вәлиев

**Ямансулап йөрү** Озак вакыт дәвамында ямансулау, даими ямансулау. *Сәхипҗамал җиңгәсен озаткач, Гөлшаһидә берничә көн ямансулап йөрде.* Г.Әпсәләмов. *Айратны кыйнап ташлагач, бераз басынкыланып калды, ямансулап йөри башлады ул.* Г.Гыйльманов

**Ямансулап калу** Берәр тәэсирдән, вакыйгадан соң ямансулау. *Шау игеннәр күчкән бураларга, Ямансулап калган басулар.* Н.Әхмәдиев. *Урамнар яктырды, агачлар, йортлар, киресенчә, караеп, ямансулап калдылар.* Г.Гыйльманов

**Ямансулап кую** Аз гына ямансулау. *Ямансулап куйдым исә, Җанымны күмә сагыш.* Ф.Тарханова. *Житәкче нинди мәсьәләдән читтә кала бит, дип ямансулап куйдым.* Безнең гәҗит

**Ямансулап тору** Әледән-әле, еш ямансулау; хәзер ямансулау. *Алай да тышка карап, ямансулап торып кына булмый.* М.Маликова. *Хәләлем, йомшак, мәхәббәтле куллары белән муеныма сарылып, битем очыннан үбеп, очып диярлек чыгып киткәч, бераз ямансулап тордым да өебездән ерак түгел генә урнашкан «Бәхетле» кафесына юнәлдем.* Г.Гыйльманов

**Ямансулап утыру** *сөйл. к.* **ямансулап тору**. *Алай да, язлар үтте, көзләр җитте дип, ямансулап утырмыйбыз.* Шәһри Казан. *Фатирыбызда ремонт эшләре дә «коткарды», ямансулап утырырга вакыт булмады.* Туган як

**Ямансулый башлау** Ямансуларга тотыну. *Гармунны, Асиям авырып китеп бик ямансулый башлагач кына, бераз күңеле ачылмасмы дип, сатып алып биргән идек.* Г.Әпсәләмов. *Ямансулый башладымы, гел исенә төшә.* В.Имамов

**ЯМАНСУЛЫК** *и.* Ямансу булу халәте. *Үзәннәрне баскан тын моңсулык. Йөрәкләрне кыса ямансулык.* К.Сибгатуллин. *Аның да күңелен бизәкле рәшәдәй моң, ямансулык сарган.* М.Маликова

**ЯМАНСЫ** *с. сөйл. к.* **ямансу**. *Ул вакытта ничек дип җырлыйлар иде әле? Минем ямансы көннәрем, Сайрама, кош, исмә, җил...* М.Мәһдиев

**ЯМАНСЫЛА́У** *ф. сөйл. к.* **ямансулау**. *Аерылышу аркасында ямансылап уйчанланган йөзләр яктырды.* Г.Әпсәләмов. *Әллә шатлыктан иде күз яшьләрем, әллә ямансылап – белми дә калдым.* А.Гыйләҗев

**ЯМАНУ** *ф. сөйл.* Бераз ямау, төрле нәрсәне ямаштыру. *Бервакыт шулай авыру күзләрем белән яманып утыра идем.* Г.Ибраһимов. *Исламныкы булырга тиешле чатырда яманып утырган япь-яшь кызны күреп, ят кунак башта аптырап калгандай булды.* Н.Фәттах

**ЯМА́У** I *ф.* 1) Тишек-ертыкны өстәмә тукыма кисәге белән каплап тегү. *Менә аның бала чагы: тугыз яшьлек ятимә Хәят әбисе янында капчыклар ямап утыра.* Г.Кутуй // Тишелгән, искергән нәрсәләрне берәр төрле материал белән каплап ябыштыру. *Үзеннән бер генә яшькә кече булган күрше малае Гарифулла белән өендә азрак укыштыргалап, төрле уенчыклар ясап, тишелгән комган, таслар ямап гомерен үткәрде.* З.Зәйнуллин // Чокыр-чакырны тутырып, такыр, тигез итү. *Асфальт юлның җимерек урынарын ямау*

2) *күч.* Авыру әгъзаны дәвалау яки тәндәге берәр яраны төзәтү. *Син кеше булсын дип, ул айлар буе яныңнан китми баш очыңда утырды. Тәнеңне ямар өчен үз тиресен бирде.* Ф.Яруллин. *Яраларын ямап, шактый вакыт госпитальдә аунаган.* Ф.Сафин

3) *күч. гади с.* Сугу, кундыру. *Бәй, теге явыз җәһәт кенә торды да минем күз төбенә берне ямады.* Г.Афзал. *Сирай минем касыкка китереп төртте, мин дә аңа берне ямадым.* А.Гыйләҗев

4) *күч. гади с.* Берәр эшне, гаепне икенче берәүгә сылтау, сылау; ягу. *Сәяхәтнамәдә исә иезуит фальсификаторлар бабалары кылган бозыклыкларны безнең төрки бабаларыбызга китереп ямыйлар.* М.Хәбибуллин

**Ямап алу** Тиз арада ямау. *Шуңа Равил аягында басып калды һәм үзе дә тегенең аяк астына берне ямап алды.* В.Нуруллин

**Ямап бару** Даими, рәттән ямау. *Иске эзне яңа юллар ямап бара. Сикерә куян. Болан уза.* Р.Мингалим. *Моңарчы тормышның тишек-тошыгын көч-хәл белән, аннан-моннан гына ямап барган гаилә кәҗә аркасында бөтәеп китте.* З.Хөсният

**Ямап бетерү** Бик күп җирдән ямау; бөтенесен ямау. *Син әйтәсең дә бит, кем Хәлим, ярлыга сәвит булыша, дип, ярлының тишек-җыртыгын сәвит ямап бетерә алмый.* И.Гази. *Мәктәптән кайткач, Рушан чанасына ныктаза кәрзин беркетте, аның эченә яньчелеп, чегәннәр ямап бетергән иске чиләген салып, вокзал ягына ашыкты.* Р.Мирхәйдәров

**Ямап җибәрү** Бераз ямау. *[Талип:] Мә, алайса, ямап җибәр.* А.Гыйләҗев

**Ямап йөрү** Озак вакытлар ямау. *Җыен тишек-тошыкны ямап йөрергә миңа кушасың.* Р.Вәлиев

**Ямап калу** Ямарга өлгерү. *Сүз уңае килгәндә, Сүтегәнне ямап кал!* Мәкаль

**Ямап кую** Алдан ямау; тиз генә ямау. *[Мисбах:] Яшь булгач, Ибраһим байның тешен дә, кесәсен дә берьюлы ямап куяр, Алла боерса, хи-хи-хи...*

К.Тинчурин. *Теләсәк – телеп алабыз, ямап куябыз теләсәк...* Р.Харис

**Ямап тору** Даими ямау; әледән-әле ямау; әле, хәзер ямау. *Ә колхозның тишекләре күп. Аны ямап торырга кирәк.* Ф.Яруллин. *Хәтта сугыш елларында да без сыердан өзелмәдек, шуның белән тормышның ертык җирләрен ямап тордык.* Г.Галиева

**Ямап чыгу** Башыннан ахырына кадәр, тулысы белән ямау. *Тирә-юнь кардан арчылып бетмәгән: җир өсте ала-кола, гаять зур кап-кара тунны ак ямаулык белән ямап чыкканнармыни.* А.Вергазов

**Ямап яту** *сөйл.* к. **ямап тору**. *Биби карчыкның комганын ямап ята идем, партоешма Бәкер килеп керде, салмыш.* Р.Газиз

**Ямый башлау** Ямарга тотыну. *Шүрәле шул кискәгә килеп утырган да чабатасын ямый башлаган.* Хикәят. *Утның икенче ягына шул ук төстә киндер күлмәк кигән, кызыл яулык бәйләгән бер хатын утырып, оек ямый башлады.* Г.Ибраһимов

**Ямый бару** *к.* **ямап бару**. *Нигә әнесенең һәр ертык урынын ямый бармаган?* С.Поварисов

**Ямый бирү** Бернигә карамый ямау. *Яшь ана менә шул турыда озак-озак уйлап, акрын гына елап, иске күлмәген ямый бирде.* Г.Ибраһимов

**Ямый тору** Әлегә ямау. *Татарлар юкка гына, тик торганчы тун итәген ямый тор, димәгәннәр ич.* Г.Әпсәләмов

**ЯМА́У** II *и.* 1) Тишек өстенә тегеп, ябыштырып, эретеп куела торган кисәк; ямаулык. *Аннары ашыга-ашыга конторга барып идән юып кайта яисә ятагы өстенә менеп утыра да, Галиясенең сүзләрне боза-боза күңелле бытылдавын тыңлап, ямау ямарга тотына.* М.Галәү. *Рухың тузса, ямау салып кына саклап булмый икән җаннарны.* К.Сибгатуллин

2) *сөйл.* Тәндәге яра урыны, җөй. *Сугыштан калган ямаулар әле беленә*

3) *күч.* Гомуми фонда төсе белән аерылып торган өлеш, тап

◊ **Ямау өстендә ямау** Бик тузган, күп тапкыр ямалган кием турында. – *Бишмәтләрегез бик тузган бит, ямау өстенә ямау салынган, – дип, мәсьәләне икенче якка борып җибәрде.* В.Нуруллин. *Киемнәрендә ямау өстендә ямау, терлек сую, сабын кайнату, күн эшкәртү урыннарында шулар эшли.* Рөстәм Вәлиев

**ЯМАУЛЫ** с. 1) Ямау салынган, ямаулары булган, ямалган. *Ә минем өстә бер кат чалбар, ямаулы иске бишмәт, аякта чабата гына.* В.Нуруллин. *Сул якта, чаштыр-чоштыр килеп, ямаулы транспортёр лентасы шуыша.* А.Тимергалин

2) Төзәтелгән, төрле кисәкләрдән корыштырган. *Өч ямаулы тоньк тәрәзә пыяласы аша ул күренми иде.* Н.Гыйматдинова. *Ул мең ямаулы асфальт та һәрбер үткән машинага ләгънәт укып кала бугай, минемчә.* Безнең гәҗит

3) *күч.* Яралы, җөйле. *Ямаулы кулны дәвалау*

4) *күч.* Рәнҗетелгән, кителгән. *Яралы халыклар... Ямаулы йөрәкләр...* Р.Фәйзуллин

5) *күч.* Төсе белән аерылып торган, зур табы булган. *Чөнки [айгырның] төсе бик кызык: бер ягы ак, икенче ягы кызыл ямаулы.* М.Мәһдиев. *Җыр диеп атыйбыз хәзер Ямаулы такмакларны.* Ф.Яруллин

**ЯМАУЛЫК** *и.* Ямау салырга, ямарга ярарлык нәрсә (мәсәлән, материя кисәге). *Уртанчымның ыштаны теткәләнеп беткән, әнкәй, синдә берәр ямаулык заты юктыр?* А.Гыйләҗев. *Моңа кадәр өч баласын төргән балаискеләре, киемнәр, төсләрен югалтсалар да, әле ярарлык дип, кайсын төпчеп, кайсына пөхтә итеп ямаулык салды Әминә.* Г.Исхакова

◊ **Ямаулык өстендә ямаулык** *к.* **ямау өстендә ямау**. *Кием-салымнары да, тузып, күрексез төскә кергән: ямаулык өстендә ямаулык.* М.Хәсәнов. **Ямаулык та сала алмаслык** Бик түбән дәрәҗәдәге, эшкә ярамаслык. *Хәйдәр Бигичев, Фасил Әхмәт кебек бөекләребез дә катнашкан утырышта ямаулык та сала алмаслык, контроль аша узмаган ертык җырлар турында да борчылып сөйләштек.* И.Юзеев

**ЯМАШТЫРУ** *ф.* Кат-кат ямау; аннан-моннан, начар гына ямау, тегү, кайбер, аерым җирләрен генә ямау. *Вакытларын юкка әрәм итмәделәр бит: Мөхлисә карчыкның абзар-курасын сипләп, йортының да тишек-тошыгын ямаштырдылар ---, ихатасын читән койма белән уратып алдылар.* Г.Әдһәмова

**Ямаштырып алу** Бераз ямаштыру. *Әле син – ир уртасы кеше, йөрәк нык, кирәк булса, әз-мәз дәвалап, ямаштырып алырбыз үзеңне, тагын дәвам итәрбез...* К.Кара

**Ямаштырып җибәрү** Бераз ямаштыру. *Аның әле хәзер дә, әзрәк төзәткәләп, кайбер такталарын алыштырып, тишек-тошыкларын ямаштырып җибәрсәң, менә дигән көймә булып китәрлек рәте барлыгын әйттек.* М.Әмир

**Ямаштырып кую** Тиз генә ямаштыру; алдан ямаштыру. *Иртә яздан йөреп хасил булган уемты-сикәлтәләрне ямаштырып куйдылар, җыелып торган сулар кибеп бетте – рәхәтләнеп йөр дә йөр генә!* Р.Мирхәйдәров

**Ямаштырып тору** Даими ямаштыру; әледән-әле ямаштыру; хәзер ямаштыру. – *Кызым белән тишек-тошыкларны ямаштырып торабыз шунда, – диде Гайшә.* Н.Гыйматдинова. *Шулай ук, бу тамгаларны алыштырасы акча юллардагы чокыр-чакырларны ямаштырып торырга да ярап торыр иде.* Безнең гәҗит

**ЯМАШТЫРУ́-ЙӨРМӘШТЕРҮ** *ф.* Ямап, юрмәп иске-москыны рәтләү. *Әмма бу карт, бер ояга кунаклап, искергән аяк киемнәрен иске күннәр белән ямаштырып-йөрмәштереп утыручы «гакыллы сапожник»ка охшый.* Ш.Камал

**ЯМБ** *и. гр. әд.* Силлабо-тоник шигырь төзелешендә басымы икенче иҗеккә төшә торган ике иҗекле стопа. *Татар телендә басым сүзнең ахырына туры килү аркасында, татар көйләрендә гомумән ямб ритмы зур урын алып тора.* М.Нигъмәтҗанов. *Бу юлы инде ул мине шигырь теориясе белән таныштыра башлады: ямб, хорей, дактиль һәм тагын әллә күпме, әйтә башласаң, телне сындыра торган терминнар.* Р.Миңнуллин

**Я́МБЛЫ** *с. әд.* Ямб белән язылган. *Ямблы шигырьләр*

**Я́МЕ** *кис.* 1) Берәр эш-гамәлгә әңгәмәдәшенең ризалыгын сорау, үзенең ризалыгын белдерү, киңәшләшү төсмере бирә. *Таңга кадәр вакыт җитәрлек, калыйк, яме?* Н.Фәттах. *Бөрлегән дигәннән, яр астында быел бигрәк күп, җыярбыз әле, яме?* А.Әхмәтгалиева

2) Сорау яки өндәү җөмләдә фикертәкъдимне, теләкне, шулай эшләргә яки әйтергә кирәклекне искәртү өчен кулланыла. *Бер сүзем дә юк, тик син, зинһар, мине бу хакта кисәтеп куй, яме?* Г.Гыйльманов. *Алайса син, Нурияkәем, миңа «Татар әбекәй» дип әйт, яме!* Г.Якупова

3) Әңгәмәдәшенең соравына, үтенеченә җавап буларак килеп «хуш, ярый, ярар, яхшы» мәгънәсен белдерә. *Я ярар алайса, өйгә кергәч укырмын, яме.* М.Хуҗин

**ЯМИН** *и. гар. иск.* Ант. --- *әгәр дәүләтле вә тугры адәм булсаң, һәрзаман*

*халык синең сүзеңә ышанучан булыр, ямингә хаҗәт калмас.* К.Насыйри. *Бу серле ямин кәгазенең төбе кая бара?* М.Гафури

**ЯМИН ИТҮ** *ф.* Ант итү. *Ямин иткәч, хатын дәхи ышанып рөхсәт бирде.* К.Насыйри. *Вөҗданым сатмам, дип иттем ямин ---.* М. Җәлил

**ЯМИНЛЕ** *с.* Антлы, ямин иткән. *– Ләкин Ишми ишан, судка килеп кергәч тә, озын чапаны белән тузаннарны себерә-себерә тезләнде, – дип яза Г.Буби бу турыда, – үзе яминле булса да, кеше рәтеннән ант итте.* М.Мәһдиев

**Я́М ЙОРТЫ** *и. тар.* Ямчылар ат алмаштыра торган станциядәге почта пункты, шуның бинасы. *Җәллад Брагинны Ногай юлындагы Талкыш күленә батырып үтерәләр, губерна үзәге булган Оренбург белән элемтә тотучы берничә ям йорты яндырып бетерелә.* Мәдәни җомга

**Я́М ӨЕ** *и. тар. к.* **ям йорты**. *Юл буендагы ям өе*

**Я́М ЧАБУ** *ф. тар.* Ямчы булу, ямчылык хезмәтен үтәү. *Автобуста шәһәр әйләнәм мин, Кыңгыраулар чыңы күңелдә: Кучер Вафа Әлмәт урамыннан Ям чабадыр сыман бүген дә.* Э.Мөэминова. *Инде менә ям чаба торган олы юлга да килеп чыктылар.* Җ.Рәхимов

**ЯМЧЫ** *и. тар.* Ям чабучы; почта йөртүче. *Кеше югалткан ямчыны кутузкага ябалар.* Г.Гомәр. *1915 елда Сәгадәт абзый Тубылга күчеп килә һәм ямчы булып почтага эшкә урнаша.* Т.Әйди

**ЯМЧЫЛЫК** *и. тар.* Ямчы хезмәте. *Алтын Урдада ямчылык хезмәте иксез-чиксез империянең кан тамырлары системасына тиң булган.* Я.Шәфыйков

**ЯМЧЫЛЫ́К ИТҮ** *ф.* Ямчы булып хезмәт итү, ям чабу

**ЯМЧЫЛЫ́К КЫЛУ** *ф. к.* **ямчылык итү**. *Эшең ямчылык кылу булгач, берни эшләр хәл юк, һәммәсен дә кайгыртырга туры килә.* Ф.Сафин

**ЯМЩИК** *и. рус тар.* 1) *к.* **ямчы**. *Пароходтан төшүгә, безне бер көтү ямщиклар чолгап алдылар.* Гали Рәхим

2) *сөйл.* Кешеләр йөртә торган һәм ямщигы булган атлы экипаж. *Ямщиктан төшкәч, мин берничә минут бу зур ике катлы йортны каранып тордым.* Ф.Әмирхан

3) *сөйл. к.* **ям**. *Солтан бабай шулай ук үзенә тигән иманада иген иккән һәм, кыр эшләреннән бушаган чакларында, Казан–Чистай арасында ямщик чапкан.* В.Нуруллин

**ЯМЩИКЛЫК** *и. тар. к.* **ямчылык**. *Пенза, Сембер губерналарыннан татарларның бирегә күпләп күченеп утырулары XVIII йөзнең 30 нчы елларында башлана (чик буйларында нығытылган пунктлар төзү, ямщиклык хезмәтен оештыру һ.б.).* Ф.Хисамова

**ЯМЬ** *и.* 1) Матурлык, хозурлык. *Бакчага ямь керә, Хуш исләр бөркелә, Сиреньнәр чәчәккә бөреләнсә.* М.Ногман. *--- әле генә җиһанга ямь биреп яшел килеш тибрәлгән яфраклар, инде сагыш төсе иңдереп, әкрен генә чиксез мәңгелеккә китеп баралар.* А.Әхмәтгалиева // Чисталык, пөхтәлек, бизәлеш. *Күзем барыбер төшә бүлмә ямене.* Р.Фәйзуллин

2) Күңелендәге җылылык, рәхәтлек; тормыш кызыгы. *Синсез урманда, умарталыкта ямь бетә.* А.Гадел. *Чуар, алама койрыклы этен ияртеп, җиде яшьләрдәге сипкелле бер малай кергән иде, алар да монда юанырлык ямь тапмадылар.* А.Гыйләҗев

**ЯМЬ-** *кис. Яшел* сүзенең мәгънәсен көчәйтә торган алкисәкчә. *Бу юлы, карасам, янымда гына, ямь-яшел чирәмлектә бик матур, берләре чуар-чуар, берләре сап-сары тавык чебешләре йөри.* А.Хәсәнов

**ЯМЬЛӘНДЕРҮ** *ф.* 1) Ямь бирү, ямьле итү; матур, күңелле итү. *Мәхәббәт тормышны ямьләндерә, бизи, рәхәт бирә, диләр.* Г.Әпсәләмов. *Хуш исләр бар бүлмәләргә таралып, бәйрәм тантанасын тагын да ямьләндерәләр.* А.Нәҗми

2) Матурлау, берәр нәрсә белән ямь өстәү. *Агач утыртып, авылны ямьләндерделәр*

**Ямьләндереп җибәрү** Бераз ямьләндерү. *Аның тезләрен югары чөеп, аякларын алга селтәп атып йөгерүе, картлар ярышын гына түгел, бөтен сабан туен ямьләндереп җибәргән иде.* М.Хуҗин. *Эре бизәкле кара, озын күлмәге, ак шәл чуклары белән уралып, арык кына ыспай гәүдәне шактый тулыландырып, ямьләндереп җибәргән.* Г.Әдһәмова

**Ямьләндереп тору** Даими ямьләндерү; хәзер ямьләндерү. *[Сандугачның] саф тавышы зәңгәр күкләргә ашкан, йокыдагы кешеләрне уяткан, җирнең иртәсен үзенә бер ямь белән ямьләндереп торган.* Д.Аппакова. *Кызганыч, безнең якларда нарат юк, аның каравы алмагачлар, тирәкләр авылны ямьләндереп тора.* Р.Кәрами

**ЯМЬЛӘНҮ** *ф.* Матурлану, ямь керү, күңелләләнү. *Анда гөлләр аллана, Тал буйлары ямьләнә. Чыркылдашып, үйнашып, Кошлар-кортлар җанлана.* М.Җәлил. *Дөнья ямьләнә. Үзеңнән дә шуңа яңа ямь өстисе килә...* Р.Фәйзуллин

**Ямьләнә бару** Торган саен ямьләнү. *Гаиләгә балалар өстәлгәч, тормыш тагын да тулылана һәм ямьләнә барды.* Р.Зарипов

**Ямьләнә башлау** Ямьләнергә тотыну. *--- әле бер-ике көн төшендә генә ямьләнә башлаган, таллы-болынлы Агыйдел буйлары сыман яшәрә башлаган дала, кешеләр – барысы да яңадан ямьсезләнеп, котсызланып калды.* Н.Фәттах

**Ямьләнә төшү** Бераз ямьләнү; тагын да ямьләнү. *Янган каенны да төбе-тамыры белән алып киткәч, бакча бөтенләй ямьләнә төшә.* Ф.Яруллин

**Ямьләнеп алу** Беразга ямьләнү. *Чүл март-апрель айларында гына бераз ямьләнеп ала да, май аенда инде үсемлекләрнең күбесе корып бетә, әйләнә-тирәдә талымсыз саксавыл белән әрсез янтак кына күзгә чалына.* Г.Тавлин

**Ямьләнеп бару** Акрынлап ямьләнү. *Шәһәрнең чырае төзекләнеп, ямьләнеп бара.* Ф.Хатипов

**Ямьләнеп калу** Бер эш, вакыйга ахырында ямьләнү. *Өй эче иркенәеп, ямьләнеп калды.* М.Кәбиров. *Акчәчәк әби килгәч, Гөбеттин бабайның дөньясы түгәрәкләнеп киткәндәй булды. Өй яктырып, ямьләнеп калды.* Р.Гарипов

**Ямьләнеп китү** Шактый ямьләнү. *Шул шкаф башларына матур вазалар да куеп чыккач, бүлмәләр тагын да ямьләнеп китте.* Г.Әпсәләмов. *Барысы да кайтып җыелгач, өйләре тагын да ямьләнеп китә.* А.Хәйретдинова

**Ямьләнеп тору** Даими ямьләнү; вакытлыча ямьләнү. *Ул вакытларда елан да, матур сурәтле булып, канатлары да кызыл, яшел төсләр белән ямьләнеп тора иде.* Ф.Яхин

**ЯМЬЛӘТҮ** *ф. сир. к.* **ямьләндерү**. *Язмыш каләме язды – Хак куштымы Ямьләтергә сиңа шушы көнемне?!* Р.Гаташ

**ЯМЬЛӘ́Ү** *ф. сөйл. к.* **ямьләндерү**. *Тормышны күбрәк ямьләп яшәп китәсе килә!* Р.Фәйзуллин. *Күп тә үтмәде, пешекчеләр эшләрен тәмам иттеләр, олы җиз самавыр да өйне ямьләп үз урынын алды.* Р.Кәрами. *Гел үсеп торсын иде Өстәлдә, ямьләп өйне, Ләззәтләндереп мине.* Р.Корбан

**Ямьләп җибәрү** Бераз ямьләү. *Йорт эчен ул тагын да ямьләп җибәрде.* Ф.Яхин

**Ямьләп тору** *к.* **ямьләндереп тору**. *Авыл түрен ямьләп тора яңа бер йорт.* С.Гәрәева. *Табигать, балачак, яшьлек, мәхәббәт һәм бәхет турындагы бу шигырьләр китапны, һичшиксез, ямьләп торачак.* Р.Миңнуллин

**ЯМЬЛЕ** *с.* **1.** Матур, хозур. *Урманнар ямьле, таулар ямьле, болыннар ямьле, әмма иген басуы барысыннан да ямьлерәк.* Г.Әпсәләмов. *Табигатьнең иң хозур, иң ямьле вакыты.* В.Нуруллин // Күңелле. *Кичәләр ямьле булсын!* А.Гыйләҗев

**2.** *рәв. мәгъ.* Матур, күңелле итеп. *Ә бит башка көннәрне дә Үткәрдек ямьле генә.* В.Хәйдәрова

**ЯМЬЛЕЛӘНДЕРҮ** *ф. ялг. к.* **ямьләндерү**. --- *озакламый, керосинка өстенә куелган чәйнек, класс бүлмәсен ямьлеләндереп, пар бөрки башлады.* Г.Бакиров

**Ямьлеләндереп тору** *к.* **ямьләндереп тору**. *Җәй буе бакчаны ямьлеләндереп тора.* Заман сулышы

**ЯМЬЛЕЛӘНҮ** *ф. ялг. к.* **ямьләнү**. *Июль, август, сентябрь айларында тагы да ямьлеләнә ул.* М.Зарипов

**Ямьлеләнеп китү** Кинәт яки бераз ямьлеләнү. *Өйгә җылы төшкәч, бүлмә эче тагы да ямьлеләнеп киткән кебек булды.* М.Хәсәнов

**ЯМЬЛЕЛЕК** *и.* Матурлык, ямьле булу сыйфаты. *Авылның утырган җире гаҗәп матур иде, монда кечкенә авыллар тирәсендә генә очрый торган ниндидер үзенә бер ямьлелек бар иде.* Ә.Еники. *Акчарлак күле белән шомыртлык арасында үткән Сабантуйларның ямьлелеге!* Ф.Садриев // Чисталык, пөхтәлек. *Мин үземне белә башлаганнан бирле, дәүләт байлыгыбыз мулдан булмаса да, иминлек һәм ямьлелек хөкем сөргән өебездә кот бетте.* Л.-Х.Таналин

**ЯМЬСЕЗ** *с.* **1.** 1) Төсе-бите, кыяфәте матур, чибәр булмаган, күрексез, шыксыз. *Көзгедә нинди кыяфәтсез, нинди ямьсез бер хайван күренә.* Г.Тукай. *Син минем өчен чын алиһә, Ямьсез кызлар, сеңлем, булмый да.* А.Нәҗми // Гарип. *Авылда мутация белән туган ямьсез кешеләр дә булды.* Безнең гәҗит

2) Тышкы күренеше гармонияле булмаган, шыксыз, тупас итеп эшләнгән. *Ямьсез биналар. Ямьсез күлмәк*

3) Хозуры, рәхәте булмаган, бик салкын, җилле, яңгырлы. *Хәер, мондый ямьсез төннәрдә аек булса да бик ашыгып йөрми ул.* В.Нуруллин. *Март башларындамы, апрель ахырындамы, бик буранлы ямьсез бер көндә безнең Курмышта булды ул эт туе.* А.Хәсәнов // Куркыныч, дәһшәтле. *Тагын ямьсез болыт килә, әнкәсе...* А.Гыйләҗев

4) Ис сизү органнарына авыр тәэсир итә торган, җирәндергеч. *Урамда очраган сукбайлар, алкашлар, йолкышлар, болай гына исереклəр, ямьсез ис аңкыткан хатын-кызлар, бүтәннәрдән аерып, аңа күз кысалар, сүз каталар – үз итеп санауларын белдерәләр иде.* А.Гыйләҗев

5) Күңелсез, борчулы, гамьле. *Эх, ямьсез уйларны ак болытларга төреп булса...* А.Мансуров. *Балалар кайгысы аларның яшәешен ямьсез һәм мәгънәсез иткән.* Г.Гыйльманов

6) Күңелдә авыр тәэсир калдыра торган. *Бүген ямьсез төшләр дә күреп бетердем шунда.* А.Алиш. *Сәлимнең, егет горурлыгын югалтып, малай кебек үкереп елавы Газинурның күңелендә бик ямьсез тойгы уятты.* Г.Әпсәләмов

7) Начар, кешеләр тискәре дип санаган; оят, гөнаһ. *[Нургаян:] Әйтсәм дә инде, килен. Бик ямьсез хәл.* А.Гыйләҗев. *Ләкин автор мәсьәләгә конкрет бер язмыш ноктасыннан торып карый, әлеге тулаем кире кагылырга тиешле ямьсез факт артында кеше язмышы ятканын күрсәтергә алынуын, героиня язмышының фаҗигалы асылын ача.* А.Әхмәдуллин

8) Әшәке, яман. *Бер-беребезне күралмау, ямьсез көнчелек галәмәте безнең һәркайсыбызда бүген дә, вагоны белән генә түгел, эшелоны белән.* А.Хәсәнов. *Медицина учреждениесендә бюрократлык – үтә ямьсез эш.* Г.Әпсәләмов

9) Тупас, күңелгә ятышсыз. *Фу, нинди ямьсез, тупас, каба мещан сүз!* Гали Рәхим. *Бары тик ямьсез авазлар гына бүлмәмә саркып керә.* А.Мансуров

10) Сүгеп, җәберсетеп әйтелгән. *Бу ямьсез әрләүнең шаһиты булган Әмир Мәҗит улы балалар алдында тыныч кына сүз башлады ---.* А.Хәйретдинова. *Аракы эчкәч, синең күзеңә ак та, кара да күренми башлый: кырасың, җимерәсең, әнине дә, мине дә ямьсез сүзләр белән мыскыл итәргә тотынасың.* А.Әхмәтгалиева

11) Түбән бәяләнә торган; сыйфатсыз, зәвыксыз. *Алар ямьсез эчтәлекле китаплар тууга китерә түгелме?* А.Мансуров

12) Әхлакый яктан түбән, оятсыз. *Ә ямьсез даны чыккан тәрбиячегә балалар ничек караганын сөйләп тормасам да чамалыйсыз булыр.* В.Нуруллин. *Сиңа ямьсез тәкъдим ясап йөргән ирләр өеренә ничек күренерсең?* А.Гыйләҗев

13) Җәмгыятьтә тискәре бәя алган. *Тамгалы ич мин хәзер, ямьсез кеше, пычратуым мөмкин.* А.Гыйләҗев

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Матур түгел, шыксыз итеп. *Мыеклары сирәк икән аның, төссез, ямьсез тырпайган мыеклар.* А.Гыйләҗев

2) Зәвыксыз, килешсез итеп; искемоскы киеп. *Алагаем, үзе шундый ямьсез киенгән, нәкъ менә бакчада апасы ясап куйган карачкы инде.* С.Зыялы

3) Тиешсез рәвештә, кирәк булмаганча. *Ә ул әле һаман пудра ягынып бетерә алмый, пудра ямьсез төште дип, яңадан битен юып ята.* Г.Камал

4) Күңелгә ятышсыз итеп. *Икенче яктан Аждаһа кача-поса керә, кулын уып шатлана, ямьсез итеп көлә-көлә чыгып китә.* А.Гадел. *Су үгезе, чын үгез булып, иләмсез үкерә, сыеры авыл көтүендә йөргән сыерлардан болай ямьсез мөгри икән.* А.Хәсәнов

5) Әшәке сүзләр белән, тупас итеп. *Кайсысыдыр ямьсез итеп сүгенеп алды, кемдер шаркылдап көлде.* А.Алиш. *Үзе, урысча катнаштырып, ямьсез, кара, пычрак сүгенде.* Г.Ибраһимов

6) Әдәпсез рәвештә, тәрбиясез итеп. *Тагын бер кат әйтәм: сез үзегезне ямьсез тотасыз.* Т.Миңнуллин

7) Усал итеп, нәфрәт белдереп. *Утырышалар, димчеләр, күңелләреннән дога укысалар да, бер-берсенә ямьсез карашып, кәнәфи читенәрәк кучеп утыралар.* А.Гадел

**3.** *и. мәгъ.* Матур булмаган яисә матур дип бәяләнмәгән зат, әйбер яки күренеш; ямьсезлек. *– Шулай да, егет, матур белән ямьсезне аера белмисең икән әле, – дидем.* А.Шамов

**ЯМЬСЕЗГӘ** *рәв. диал.* Ямьсез булып, ямьсез рәвештә. *Югыйсә биябезнең бер колынлау белән тупасланып, ямьсезгә калынаеп китүе бар.* А.Хәсәнов

**ЯМЬСЕЗЛӘНДЕРҮ** *ф.* 1) Ямьсез итү, бозу. *Болай да шөкәтсез чыраемны вазелин тагын да ямьсезләндергән иде.* Р.Батулла

2) Ямьсез итеп күрсәтү. *Тик, беренчедән, аның теге чактагы сөенечен бетерермен һәм, икенчедән, аның шаяртуыннан соң Рәшит абыйның бер мизгелгә онытылып елмаюын ямьсезләндерермен кебек.* М.Хуҗин

**Ямьсезләндереп тору** Һәрвакыт ямьсезләндерү; әле, хәзер ямьсезләндерү. *Хуҗасыз йортлар тирә-юнь авыллары-*

*бызны ямьсезләндереп тормасын өчен дә тиешле чаралар күрелсен.* Йолдыз

**ЯМЬСЕЗЛӘНЕШҮ** *ф. сөйл.* 1) *урт. юн. к.* **ямьсезләнү**

2) *күч.* Үзара мөнәсәбәтләрне бозу; бозылышу, ачуланышу. *Беренче очрашуда ук сездәй кадерле кунаклар белән ямьсезләнешәсе килми...* Ш.Маннур. *Шуның аркасында ямьсезләнешәләр килен белән.* Т.Миңнуллин

**Ямьсезләнешеп алу** Бераз ямьсезләнешү. *Икенчесе – Пасха бәйрәме көнне исерешеп, ямьсезләнешеп алу хәлләре.* Татар әдәбияты

**Ямьсезләнешеп бетү** Бик нык ямьсезләнешү; күпләр белән ямьсезләнешү. *Ул Чистайга Исхак мулланы китертмәс өчен ямьсезләнешеп бетә.* Р.Батулла. *Үз тормышының да рәте-чираты юк, бөтенләй ямьсезләнешеп бетәрләр.* Г.Бәйрәмова

**ЯМЬСЕЗЛӘНҮ** *ф.* 1) Чибәрлеге китү, матурлыгы югалу. *– Әгәр гомерем буе кибет идәнендә кырын ятып торсам, мин дә синең төсле каралыр һәм ямьсезләнер идем, – дип җавап бирде.* Г.Тукай

2) Ямьсез хәлгә килү, тышкы кыяфәте бозылу, шыксызлану. *Күлмәкнең төсе уңып ямьсезләнгән*

3) Рәхәте китү, кызыгы бетү. *Тормыш ямьсезләнү*

4) Бозылу, шыксызлану (һава торышы тур.). *Бүген битләрне аяусыз чәнчеп, кием-салымнарны әрсез йолыккалап, туктаусыз коры салкын җил исте, суытты, көн ямьсезләнде.* А.Гыйләҗев

5) *күч.* Әшәкеләнү. *Хәзер әллә ничек кырысланды, ямьсезләнде сүзләр.* Н.Сафина

6) Тәртип бозу; әдәпсезләнү, оятсызлану. *Әгәр син кичә ямьсезләнеп миңа бәйләнсәң, шунда ук күңелем суынып иде.* К.Кара

7) Берәү белән сүзгә килү, телләшү. *Шуннан соң да акылга утырмады Зәки абый: җае туры килгәндә лыкынганчы эчеп, кеше белән ямьсезләнеп, тәмсез телләнеп йөрүен дәвам итте.* В.Нуруллин. *Берзаманны, силос өчен ямьсезләнеп, Телгә килде Бахбай белән Сыерҗамал.* Г.Афзал

**Ямьсезләнә бару** Торган саен ямьсезләнү. *Тумыштан чибәр булып яратылганнар усаллыклары аркасында ямьсезләнә бара.* Р.Батулла

**Ямьсезләнә башлау** Ямьсезләнү билгеләре күренү. *Әнә көн тагын ямьсезләнә башлады.* М.Хәбибуллин. *Ләкин бу дуслык көннәрдән бер көнне бозыла, ямьсезләнә башлады.* Н.Фәттах

**Ямьсезләнеп бетү** Тәмам, бик нык ямьсезләнү. *Аның гарипләнеп, ямьсезләнеп беткән кыяфәте Нэллины котсыз калдыра.* З.Хәким

**Ямьсезләнеп калу** Билгеле бер хәлдән соң ямьсезләнү. *Элегрәк Кәримә авылда матур кызлардан санала иде, хәзер инде ул сулып, ямьсезләнеп калган.* М.Галәү. *Мәктәп караңгыланып, ямьсезләнеп калды.* Г.Мирһади

**Ямьсезләнеп китү** Кинәт ямьсезләнү. *Каникулдан соң көннәр бик ямьсезләнеп китте дә, мин дүрт көн Солтаннан кайта алмадым.* В.Нуруллин. *Шул яңалыгын әйткәч, йөзе отыры караеп, ямьсезләнеп китте; болай да моңсу карашы тагы да моңсуланды.* Р.Камал

**Ямьсезләнеп кую** Кинәт яки бераз ямьсезләнү. *Тик бер көнне генә күгем болытлап, ямьсезләнеп куйгандай булды.* Җ.Рәхимов

**Ямьсезләнеп тору** Әледән-әле ямьсезләнү; әле, хәзер ямьсезләнү. *[Нәсел тәкәсе меринос] Танавын җыерып, күзләрен тондырып ямьсезләнеп тора, чуртумайтери.* М.Мәһдиев

**ЯМЬСЕЗЛӘТҮ** *ф. к.* **ямьсезләндерү**. *Син Тәнзиләнең япь-яшь кыз икәнен дә, наивная икәнен дә онытып җибәрәсең, ямьсезләтәсең.* Ф.Яруллин. *Эчмә, дидем бит инде мин сиңа, сине ямьсезләтә генә бит инде аракы.* Х.Әбделмәнов

**Ямьсезләтеп бетерү** Бик нык ямьсезләтү. *Аны куйганда, бер малай бозып, ямьсезләтеп бетергән.* Казан утлары

**Ямьсезләтеп тору** Даими ямьсезләтү; әле, хәзер ямьсезләтү. *Шунысы күңелсез: ташландык йортлар авыл йөзен ямьсезләтеп тора.* Авыл таңнары. *Кайбер тузган, буш йортлар шәһәребезнең тышкы күренешен бигрәк тә ямьсезләтеп торалар: ватык тәрәзә рамнары, челпәрәмә килгән пыялалар, ишелгән түбәләр...* Чистай хәбәрләре

**Ямьсезләтеп чыгу** Һәммәсен берберр артлы ямьсезләтү. *Әгәр кодрәтеннән килсә, Зәбир үзеннән башка бөтен яшь ир-атларны ямьсезләтеп чыгар иде.* Ф.Яруллин

**ЯМЬСЕЗЛӘ́Ү** *ф. к.* **ямьсезләндерү**. *Син аларның итәкләренә карама, андагы фашист үләксәләре, табигатьне ямьсезләп, озак ятмас.* Г.Әпсәләмов. *Кайбер ирләр кебек, хатын яманлап, узган тормышын ямьсезләп сөйләп йөрми.* Г.Бәйрәмова

**Ямьсезләп бетерү** Тәмам ямьсезләү. *Миләүшә табындагы бар нәрсәләрне дә капкалап, ямьсезләп бетерде.* Ф.Яруллин. *Җилләр, яңгырлар, карлар, кояш эссесе ямьсезләп бетергән, тик мәңгегә йомшак һәм җылы калган бишегемне.* Ә.Гаффар

**Ямьсезләп җибәрү** Бераз ямьсезләү. *Йөзендәге кызарып торган җөй эзе Фоатны бөтенләй ямьсезләп җибәргән.* Ш.Маннур

**Ямьсезләп кую** Кинәт ямьсезләү. *Шушы бер очраклы вакыйга белән мактанып, дөрес яшәлгән гомернең матур чынбарлыгын ямьсезләп куяргамы?* К.Кәримов

**Ямьсезләп тору** Даими ямьсезләү; әле, хәзер ямьсезләү. *Корыган тупыл авылны ямьсезләп тормасын, диячәкләр.* Р.Батулла. *– Нигә һаман шул төпне алып атмыйсың инде, бар бакчаңны ямьсезләп тора, – диләр.* Г.Гыйльманов

**ЯМЬСЕЗЛӘШҮ** *ф. ялг. к.* **ямьсезләнешү**. *Аяк чалышмыйк, бер-беребезне йөгәнләргә тырышмыйк, тәмсезләшмик, ямьсезләшмик.* Зәй офыклары. *Ишетмәдегезмени, хатыны белән ямьсезләште ич.* Өмет

**Ямьсезләшеп бетү** Тәмам ямьсезләшү. *Урын бүлешеп, ямьсезләшеп беткән төбәкләр дә бар...* Акчарлак

**ЯМЬСЕЗЛЕК** *и.* 1) Ямьсез булу сыйфаты, шыксызлык. *Балчыктан ясалган йортлар, землянкалар үзләренең кечкенәлеге, ямьсезлеге белән безнең сәйяхларның дикъкатен җәлеп кылды.* Г.Гобәйдуллин. *Башыннан алып аягына тикле бу кадәр ямьсезлекне табигать каян һәм ничек табып бетергәндер, дип уйлый Азат.* А.Тимергалин

2) Катлаулылык; авырлык. *Бикә үзенең Мәрьямен, Мәрьям туташлыкка хәзерләп, авыл тормышының тупаслыгыннан һәм ямьсезлегеннән тәмам аера алды.* Г.Ибраһимов. *Тормышның шундый ямьсезлеген кичергән Васия шундый ук хәлгә тарыган Саримәне бәхетсезлектән йолырга тиеш булды – тормыш дигәнеңнең аңлашылып җитмәгән әкәмәтләре бар инде аның, бар...* М.Хуҗин

3) *күч.* Әшәкелек, пычраклык; түбәнлек; тупаслык. *Әнисе, апасы күреп, белеп торсын иде: алар арасында ямьсезлек юк, икесе дә былбыл балаларына тиң гөнаһсызлар иде.* А.Гыйләҗев. *Тискәре персонажны башкарганда, мин рольгә бөтен нәфрәтемне салам, аны бөтен түбәнлеге, ямьсезлеге белән күрсәтергә тырышам.* Р.Юныс

**Я́МЬ-ТӘМ** *җый. и.* Рәхәт; кызык; матурлык. *Яшәүнең ямь-тәме бетте, – кеше «нуль» булып калгач, түрә-«хөкемдарлар» аяк чалгач.* К.Латыйп. *Монда тыныч! Монда ямь-тәм! Кал син монда!* Р.Фәйзуллин

◊ **Ямь-тәм табу** Рәхәтләнү, канәгатьлек кичерү. *Шунда күпме хәбәр ишетәсең, тел чарлыйсың, үзеңә күрә күңел бушатасың, сөйләшү-хәбәрләшүдән ямь-тәм табасың.* Г.Хөсәенов. **Ямь-тәм тапмау** Эч пошу, күңелсезләнү, сагышлану. *Чит җирләрдә ямь-тәм тапмыйм*

**ЯМЬШӘЙТҮ** *ф.* 1) Ямьшек итү; формасын бозу. --- *полк командиры снаряд гильзасыннан ямьшәйтеп ясалган сукыр лампадан яртылаш коелган папиросын кабызды ---.* З.Әхмәтҗанов. *Эшнең шундый борылыш аласын сизенгәнмен: машинаның номерын хәтерләдем, аннан язып куйдым – машинамны ямьшәйтте, тәрәзәмне ватты.* Т.Галиуллин

2) *күч.* Авызны кыйшайту, йөзне сыту. *Хатип, авызын ямьшәйтеп кенә миңа карап алды да, ирониялe бер кыяфәттә селкенеп кеткелдәп куйды.* М.Яһудин

**Ямьшәйтеп җибәрү** Бераз ямьшәйтү. *Шушы җирдә авызыңны ямьшәйтеп җибәргәндә дә аш булыр иде инде сиңа.* М.Фәйзи

**ЯМЬШӘЮ** *ф.* Тапталу, изелү, таушалу һ.б.ш. сәбәпләрдән формасы бозылу, яньчелү, кыйшаю. – *Әнә, – диде Сәләхетдин, гомер буе сугылудан һәм кысылудан тырнагы ямьшәеп, каралып беткән чәнчә бармагы белән Илһамга күрсәтеп.* Ф.Садриев. *Без, иске бараклар, ямьшәеп җиргә иңә язган йортлар арасыннан үтеп, колонка янына барабыз.* Ф.Җамалетдинова

**Ямьшәеп бетү** Бик нык ямьшәю. *Ул, сестра алып чыкмый торган көннәрдә, иртәнге обход беткәч, ямьшәеп беткән яшел фуражкасын кия дә дежурный лекпом янына бара.* А.Шамов. *Ялан аякларына үкчәләре кыршылып, ямьшәеп беткән резин итекләр элдергән.* А.Гыйләҗев

**Ямьшәеп калу** Билгеле сәбәпләр аркасында ямьшәйгән хәлгә килү. *Салам сыйрак чүмәлә баштан сыгыла сыман... Елап туган – авызы еламсырап, ямьшәеп калган да һаман тураймаган.* Ш.Галиев

**Ямьшәеп китү** Бераз ямьшәю. *Мәзәк сөйләүчене колак торгызып тыңлыйм мин: шул чакта кан сыекланып, күзләр кызарып, авызлар ерылып, алай гына да түгел, йөзнең ярты ягы уң якка ямьшәеп тә китә икән.* Т.Нәҗмиев

**Ямьшәеп тору** Даими ямьшәю; әле, хәзер ямьшәйгән булу. *Тузган итек кунычыдай Гармунланып, Ямьшәеп торган иске йортны Авыл белән килеп Сүттеләр ---.* Ф.Яхин. *Өстендә уңып беткән соры плащ, бөгәрләнгән яшькелт күлмәк, аягында үкчәләре ямьшәеп торган туфлиләр.* Ә.Салах

**Ямьшәя бару** Торган саен күбрәк ямьшәю, һаман ямьшәю. *Бер очын корып бетергәнче, икенче очыннан ямьшәя башлый.* Язмыштан узмыш юк

**ЯМЬШЕК** *с.* 1) Ямьшәйгән, яньчелеп формасы бозылган. *Ул чатан аякларындагы ямьшек үкчәле сандалилары белән каты-каты басып, ишегалдында лап-лап атлап йөргәндә, очраган абый-апалар тотып сөяләр үзен.* Р.Фәизов. *Аның ямьшек эшләпәсе дә, фәкыйрь киеме дә күз алдында үзгәреп китә.* М.Галиев

2) Яссы, җәенке, киң. *Нигә мин шул зур колак, ямьшек борынга әти дип йөрергә тиеш ди әле?* В.Нуруллин. *Буйсыны менә дигән, ике бит алмасы янып тора, кара чәчләре иңнәренә таралып төшкән, хәтта ямьшек борын да кыяфәтен бозмый, аңа бер үзенчәлек кенә биреп тора иде шикелле.* М.Маликова

3) Кыек, кыйшайган. *Баттый олы авызлы, ямьшек йөзле иде.* М.Галиев

**ЯН** *и.* **1.** 1) Пространствода: уң кул һәм сул кул яклары. *Мичәү аты – янга җигелгән ат.* А.Тимергалин

2) Гәүдәнең җилкәдән алып янбашка кадәр уң яки сул ягы; янтык. *Алданрак килеп җиткән Ланге русларны, кыйшайган наратка яны белән сөялгән һәм сары итекле аягын чалыштырып куйган килеш, мыскыллы кыяфәт белән каршы алды.* Г.Әпсәләмов. *Көндезге сүз саранлыгыннан аптыраган Маһибәдәр, карт бөркет кебек иңкәеп, яны белән тәрәзә төбенә таянып утырды.* А.Гыйләҗев

3) Берәр нәрсәнең, өске, аскы, алгы, арткы якларыннан аермалы буларак, уң яки сул ягы. *Әгәр такта яны белән тигез булып торса, поезд үтәргә ярамый, дигән сүз.* А.Алиш. *Шактый кызу килгән тарантас та капылт кына туктап кала алмады: яны белән әйләнеп, ерым төбенә очты.* В.Имамов. – *Турыга, – дип, кулының яны белән һаваны үткен ярды ханым, алдамады.* М.Хуҗин // Күзнең, иреннең почмагы, бер очы. *Сәет оялу һәм уңайсызланудан комач төсенә кереп, күзләренең яны белән генә башка җәйдакларны айкап чыкты.* В.Имамов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Уң яки сул кул ягындагы, уңда яки сулда урнашкан, яндагы. *Каршыда гына берәүнең ян бакча коймасына терәтеп ясаган эскәмиясе дә бар иде.* А.Фәләх

2) Өстәмә, икенчел, ярдәмче. *Ян көчәнешләр*

3) Чит, тыштан килгән. *Ян тәэсир*

4) *лингв.* Һава агымы телнең ике (яки бер генә) кырыеннан чыгып ясала торган. *Ян тартыклар*

5) *биол.* Яфрак белән сабак арасындагы почмакта урнашкан, куентыктагы. *Төп сабакны озынлыкка үстергәндә, үсү матдәләре ян бәбәкләрнең үсүен тоткарлый.* Биология

◊ **Ян бирү** 1) Кемгә яки нәрсәгә дә булса ян белән борылу. *Ике кулын ике җиң эченә тыгып, аркасын бөкрәйтеп, җилгә ян биребрәк атлаган бу кешенең нинди уйлар, нинди йомыш белән баруын белсәләр, эсэсчылар, уйлап та тормыйча, аны беренче баганага тотып асарлар һәм, башкаларга гыйбрәт булсын өчен, атналар буе шуннан төшертмәсләр иде.* Г.Әпсәләмов; 2) Ачуланып, үпкәләп, кемгә дә булса ян яки арка белән тору (утыру). **Янга калу** Нәрсә дә булса тотылмый, файдаланылмый калу; сак тотылу. *Утынны янга калдырыр өчен, аз ягып, бөтен кыш буе безнең тешләрне танцевать иттерә.* Г.Камал. *Малайлар, базарга кереп, янга калган юл акчасы исәбенә аз гына сыйланмакчы булдылар.* А.Тимергалин. **Янда йөртү** Үзең белән йөртү, һәрвакыт кесәдә булу. *Бу ядкәр – һәрчак янда йөртерлек, һәрчак киңәш-табыш итәрлек тормыш дәреслеге, тәрбия китабы кебек.* Х.Миңнегулов

**ЯНАВЫЧ** *и.* Чалгы, пычак кебек эш коралларын үткенләү, янау өчен озынча кайрак; беләү. *Сыер, авыр гәүдәсен авыш-тәвеш китереп, тагын бер-ике адым алга таба атлады да үзенең кайнар, дымлы, чалгы янавычыдай кытыршы ирене, теле белән, Иргалинең сузылган кулына төртелде.* М.Хәсәнов. *Кибеттә әллә ни товар күренми – күлмәкләр, янавычлар, күсе тәбеләре һәм балта саплары гына иде.* М.Мәһдиев

**ЯНАРТА́У** *и.* 1) *к.* **вулкан**. *Япониянең табигатендә булган бозлы яңгырлар, янартауларыннан чыккан ут дәһшәтләре, җир селкенү һәлакәтләре, тайфун фаҗигалары һәр ел саен Япония өстенә йөзәр меңләгән кешеләр*

*корбаны, миллионлаган сумлык зарар китерә.* Т.Гыйззәт

2) Көчле, әмма яшерен, сиздермәскә тырышылган хисләр. *Хаммат бу сүзләрне шундый ачыргалану белән әйтте ки, Мөнирҗан дустының йөрәгендә янартаулар кайнавын аңлады.* Н.Әхмәдиев

**ЯНАРТАШ** *и. махс.* Коры куып күчерү нәтиҗәсендә составы ягыннан нефтька охшаш сумала бирә торган файдалы казылма; *русчасы:* **горючий сланец**

**ЯНАРЧӘЧӘК** *и. бот.* Канәферчәләр семьялыгыннан ачык сары яки ачык кызыл төстәге чәчәк ата торган үлән үсемлек; *русчасы:* **горицвет**. *Ә яз, җәй башында үзләренең матурлыклары, хуш исләре белән лаләләр, нәркисләр, крокуслар, янарчәчәкләр, бадаңнар, ирислар, аквилегияләр сөендергән булса, күзгә таба хризантемалар, георгиннар чәчәк атачак.* Сарман

**ЯНА́У** I *ф* 1) Кемгә дә булса куркыту ымы ясау. *Үзе көлә, үзе миңа бармак яный.* А.Алиш. *Бармак белән яныйм: «Улым, дүрт аяклы дусларны кыйнарга ярамый!»* З.Мәхмүди

2) Берәр начарлык эшләү, үч алу турында алдан әйтеп, куркытып, кисәтеп кую. *Часть командиры гаепле солдатларга, өеңә хат язам, әтиеңне чакыртып алам, дип еш яный.* С.Шәрипов. *Яшь кияү белән яшь кәләшнең, бәләкәй генә тәенчек тотып (Шәмсегаянның күлмәк-күнчегe иде тәенчектә!), бай капкасыннан текә генә чыгып китүләрен әнкәсе үкереп, әткәсе тешен кысып, янап, каргап, тәрәзәдән карап калдылар.* А.Гыйләҗев

3) Кем яки нәрсә өчендер куркыныч булу, ямьсез, куркыныч нәтиҗәләргә китерү ихтималы булу. *Аңа, гөнаһ шомлыгына каршы, ниндидер куркыныч яный кебек.* Н.Хәсәнов. *Канунны бозган чит ил ватандашларына акчалата штраф, Русиядән куылу яки, 15 тәүлеккә төрмәгә ябылып, соңыннан илдән куылу яный.* Безнең гәҗит

**Янап алу** Тиз генә янау. *Разведчикларның кайсыдыр аңа хәтта йодрыгы белән янап та алды.* Г.Әпсәләмов. *Белгән булсак, уенга да катнаштырмаган булыр идек, дип, башкалары аңа тәпи янап та алалар.* А.Хәсәнов

**Янап кую** Бер тапкыр янау. *– Кара аны, күн заводы комсомолының авторитетын төшерәсе булма, – диде, шаярып кына бармак янап куйды.* А.Алиш. *– Биргән булса, XX гасырда мин синең түрәләреңне тотып пешекләрмен әле, – дип, гасырлар аша янап та куйды Туйбикә абыстай.* А.Тимергалин

**Янап ташлау** Көтмәгәндә, кызулык белән янау. *Инженер Чермак, гайрәте чигеп, ату белән янап ташлады.* А.Толстой

**Янап тору** Гел яки әледән-әле янау; әле, хәзер янау. *Әйе, бер-беренә пычак, утлы корал белән янап торганда, дәүләтләр арасында татулашып китү җиңел хәл түгел.* А.Хәсәнов. *Замначальник тәрәзәдән карап тора, Ялкаулар, дип әрләп тора, янап тора.* Г.Афзал

**Янап яту** *сөйл. к.* **янап тору**. *Всеволодның үзенә дә Сәлим хан язмышы янап ятмый микән?* В.Имамов

**Яный башлау** Янарга тотыну. *Күзләреннән утлар чәчеп, яный ук башлады: – Әй, син! Авызыңны чамалабрак ач, яме.* М.Хәсәнов. *Эшеннән куу белән яный башлады.* А.Хәлим

**Яный килү** Әлегәчә янау. *Аның бу кыланышларына хатыны бик үртәлә, бер өйрәтәм әле мин сине дип, һаман саен яный килә.* Ф.Яруллин

**Яный тору** Һаман, даими янау; каткат янау. *– Матри у меня! – дип бармак та яный торды.* А.Хәсәнов

**ЯНА́У** II *ф.* Пычак, чалгы кебек коралларны янавыч белән үткенләү. *Болын өстен яңгыратып, әле уңда, әле сулда, көйләп-көйләп чалгы яныйлар.* Г.Бәширов

**Янап алу** Тиз генә янау. *Миңнулла, маңгаена агып төшкән эре һәм тозлы тир тамчыларын учы белән сыпырып, чалгысын янап ала да каерылып-каерылып чабуын тагын дәвам итә ---.* В.Нуруллин

**Янап бетерү** Янау эшен төгәлләү; бөтенесен янау. *[Чалгыны] Янап бетергәч, йөзенә бармагымны тидереп карадым: Гали батыр пәкесе дә болай ук үткен булмагандыр.* Ф.Шәфигуллин

**Янап җибәрү** Бераз янау. *Карт үзе белән яшьтәш булып, уртасы бер илле генә калган чалгысын түндәк башына сабы белән кадады, чаң-чоң китереп, бер-ике янап җибәрде ---.* Г.Ибраһимов

**ЯНАУЛЫ** *с.* Янау (I) белдерә торган. *Торганда, ул Идрисовка астыртын янаулы күзләренең агы белән карап алды – аның битендә кинаяле көлемсерәү иде.* Х.Камалов

**Я́НӘ** *рәв.* **1.** 1) Тагын, тагын да; тагын бер; бу юлы да. *Әмма аның кисәтүен янә исәпкә алмадылар.* А.Хәсәнов. *Бу сәер чагыштырудан күңелем янә тантана итә.* А.Әхмәтгалиева

2) Кабаттан, янәдән, яңадан. *Минем тормыш – котырынган Диңгез, Маяк сүнгән, кыйблам югалган. Бик еш кына батам, янә калкам, Янә чоңгылларда югалам.* Аманулла. *Янәшәдә әти булганда, дөнья янә матур, янә түгәрәк иде.* А.Әхмәтгалиева

**2.** *терк. мәгъ. иск.* Һәм, вә, шулай ук. *Син, мин янә ул бу эшкә алынырга тиеш*

◊ **Янә килеп** Моннан тыш; шуңа өстәп. *Янә килеп, Азат Сәйдәшевне, Көнбатыш Германиядән буш кул белән кайтмагандыр, өлешкә керсәк тә гөнаһ булмас, дип уйлаучылар табылырга бик мөмкин.* А.Тимергалин

**Я́НӘДӘН** *рәв. к.* **янә**. *Әниле булуның нинди зур бәхет икәнен әнисен бер җуеп, янәдән тапкан бала гына беләдер.* А.Хәсәнов. *Дуслар янәдән күрештеләр.* А.Нәҗми

**Я́НӘСЕ** *мод. сүз.* 1) Кемнеңдер сүзләренә, гамәлләренә сөйләүченең ышанмавын, шик-шөбһә белән каравын, кемнең дә булса фикере белән килешмәвен яки юмор, ирония, сарказм тонын белдерә. *Минем бабам сөйләгән иде, янәсе, урманда йөз елга бер мәртәбә абага чәчәк ата.* А.Гадел. *Янәсе, ул гына оста, белдекле!* А.Гыйләҗев

2) Кемнең дә булса ым, елмаю, каш сикертү һ.б.ш. хәрәкәтләренең мәгънәсен аңлатканда кулланыла. *Генри үзенең бүлмәдәшенә күз төшереп алды: күрдеңме, янәсе.* А.Тимергалин. *Илсөя, тозлы гөмбәне чәнечкесенә элэктерә алмый җәфаланган Ринатның аягына каты гына итеп басып алды, янәсе, чамаңны бел.* А.Әхмәтгалиева

3) Алда әйтелгәннәрне ачыклап әйткәндә кулланыла. *Мунча ягасыз түгелме, янәсе, чәп-чәптән мине дә калдыра күрмәгез.* А.Хәсәнов

**ЯНӘШӘ** *рәв.* **1.** 1) Берәр кеше яки берәр нәрсә белән беррәттән, бергә, янында. *Разия, сумкасын тоткан кулын селки-селки, Сабир белән янәшә атлый.* А.Алиш. *Кызлар, шау-гөр килеп, Акъегетне мактыйлар, Алтынчәч белән янәшә бастыралар.* А.Гадел

2) Бер-беренә якын итеп, күрше итеп. *Ике йортны янәшә салу*

3) Бергә; бер-берсеннән аерылмыйча. *Татарда тоз һәм ипи сүзләре янәшә йөри ---.* А.Тимергалин. *Бер-берсеннән аерылып торсыннар өчен, «булган» белән «булмаган» янәшә яратылган.* А.Хәлим

4) Бик якын урында. *Янәшә генә көмештәй саф сулы чишмә агып ята.* А.Хәсәнов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Нәрсәнең дә булса янында торган, тирәсендә урнашкан. *Янәшә корпустагы Ганҗә исемле кызга да Казанцева фамилиясе тагалар.* А.Тимергалин

2) Якын, күрше, чиктәш булган. *Кайчандыр Нәҗип белән Мудрый якын гына иптәшләр иде, бер торакта, янәшә бүлмәләрдә яшәделәр.* А.Гыйләҗев. *Янәшә басуда хатыннар актарылган чөгендерләрнең яфрагын, кисеп, өемнәргә өяләр иде.* М.Маликова

**3.** *и. мәгъ.* Аралашкан кешеләр, даирә, әйләнә-тирә дөнья. *Ап-ак мамык оча һаваларда, ап-ак минем бөтен янәшәм.* Акъегет

◊ **Янәшә кую** Бер дәрәҗәдә, тиң итеп санау. *Гадәттә, Тукайның үз сүзләренә ияреп, аны рус шагыйрьләре Пушкин һәм Лермонтов белән янәшә куюга тап буласың.* А.Тимергалин. *Ул гынамы әле, Рамилләр буыны белән янәшә дә куеп булмый бүгенге яшьләрне.* А.Хәйретдинова. **Янәшә тору** Кем яки нәрсә белән бер дәрәҗәдә булу, берсе икенчесенә тиң, лаек булу. *Янәшә торып, тигез булып сөйләшү, хезмәттәшлек итүгә ни җитә!* Р.Мөхәммәдиев. *Ә бу каһарманның исеме Бөек Ватан сугышының иң күренекле геройлары белән янәшә торырга лаек бит!* Н.Максимов

**ЯНӘШӘЛЕК** *и.* 1) Янәшә булу, якын тору хәле. *Бер яктан, Рабиганың күзләре, аның янәшәлеге егеткә чиксез бәхет, рәхәт биргән кебек тоела.* Г.Рәхим. *Шатлык белән кайгы, мәхәббәт белән нәфрәт, яшәү белән үлем янәшәлегенә ишарә итүче билгеләрме әллә алар?..* С.Зыялы

2) Охшашлык. *Ләкин биографик янәшәлекләр моның белән генә бетми.* М.Мәһдиев

3) *махс.* Параллель; параллелизм. *Отышлы чагыштырулар, кызыклы янәшәлекләр аркылы ассоциатив фикерләр уздыру, чын халыкчан телдән, диалектизмнардан, халык җырларыннан оста файдалану һ.б., оригиналь һәм зур проблемалар күтәреп, замандашларының игътибарын шуларга юнәлтергә ярдәм итә.* А.Әхмәдуллин. *Әдип чагыштыру һәм янәшәлек алымнарыннан оста файдалана.* Китапларда – тарих сурәте

4) *лингв.* Синтаксик бәйләнешнең сүз тезмәләре һәм җөмлә эчендәге сүзләрнең кушымчасыз, янәшә тору юлы белән генә үзара бәйләнүеннән гыйбарәт төре. *Сыйфат фигыль белән сыйфатланмыш арасындагы бәйләнеш төрен дә янәшәлек дип билгеләү дөресрәк булыр иде.* Ф.Хисамова. *Бу, шушы, теге, шул, ул, андый, мондый алмашлыклары сыйфатлар белән мөнәсәбәттәш, исемгә янәшәлек ярдәмендә бәйләнәләр.* Татар грамматикасы

**ЯНӘШӘСЕНӘ** *бәйл.* Эш-хәрәкәтнең билгеле предметның, затның кырыена, тирәсенә тупланып башкарылуын, шунда юнәлгәнлеген күрсәтү өчен кулланыла. *Нурулла баскыч бусагасына утырган әтисе янәшәсенә чүгәләде.* А.Фәләх. *Ул арада кулга-кул тотынышкан Ләйсән белән Барый да аның янәшәсенә килеп бастылар.* А.Гыймадиев

**ЯНӘШӘСЕНДӘ** *бәйл.* 1) Эш-хәрәкәтнең берәр предметның, затның, урынның кырыенда, тирә-ягында башкарылуын белдерү өчен кулланыла. *Шул чакта дзот янәшәсендә бер-бер артлы ике снаряд ярылды.* Г.Әпсәләмов. *Әнисе янәшәсендә бер сабый бара.* В.Нуриев

2) Берәр нәрсә белән бергә булуын белдерә. *Ут янәшәсендә су йөри...* А.Гыйләҗев. *Өстәмә антропонимик берәмлек буларак, фамилия, ата яки баба исеме, сословие титулы буларак, исем янәшәсендә кулланыла.* Г.Шәйхиева

**ЯНӘШӘСЕННӘН** *бәйл.* Эш-хәрәкәтне берәр зат, предмет, урынның кырыеннан, тирәсеннән юнәлеп, үтеп башкарылуын белдерү өчен кулланыла. *Янәшәсеннән диярлек атлаучы чабаталы аякларны күргәч, әсир сискәнеп башын күтәрде һәм җәһәт кенә аягүрә торып басты.* М.Хуҗин. *Рәсимә салмак кына ире янәшәсеннән кузгалды.* Г.Әдһәмова

**ЯНӘШӘ́-ТИРӘ** *җый. и.* **1.** Якынтирә, әйләнә-тирә, тирә-як. *Күрәсең бит, безнең басуларны карарга бөтен янәшә-тирә колхозларыннан кешеләр килгән.* Т.Гыйззәт

**2.** *с. мәгъ.* Якын-тирәдә урнашкан. *Янәшә-тирә районнарга чыгу*

**ЯНБАШ** *и. анат.* Гәүдәнең билдән алып ботка кадәр булган өлеше. *Майпәрвәз ханым киявенең тәлинкәсенә итнең иң шәп җиреннән зур түтәрәм янбаш сөяген сала.* Ә.Еники. *Гасәбә хатын култыгыннан алмакчы иде дә, аны янбашы белән этеп кенә җибәрде.* М.Әмирханов

**ЯНВАРЬ** *и. лат. к.* **гыйнвар**. *СССР язучылары съезды бик күп чигерүләрдән соң 1966 ның декабренә билгеләнгән иде. Булмады, январьга күчерелде.* М.Әмир

**ЯНГЫН** *и.* Янучан нәрсәләрне яндырып юкка чыгара торган ут. *Янгында безнең авыл кешеләре бердәм, ярдәмчел шул.* Н.Хәсәнов. *Ишек төбендә генә – янгынга каршы куелган су белән тулы зур гына агач мичкә.* А.Хәсәнов

**ЯНГЫНЛЫ с.** 1) Яныр торган, янгын эчендә булган. *Кешеләрне янгынлы йорттан исән-имин чыгара, газлы баллоннардан да котылу карарын кабул итә.* Яңарыш

2) Янгыннар булып узган; янгын очраклары күп булган. *Үткән елларның янгынлы җәйләрен онытырга да хакыбыз юк.* Туган як

**ЯНГЫНЧЫ** *и. махс.* Янгын сүндерүче. *Артта янгынчылар үтеп киткән машина, быргы тавышлары ишетелә.* Т.Гыйззәт. *Юынырга, ашарга пешерергә уңайлыклар юк, плитәдә пешерә башласаң, янгынчылар килеп ясак салалар.* Р.Батулла

**ЯНГЫНЧЫЛЫК** *и.* 1) Янгыннарга каршы көрәшү тармагы. *Янгынчылык депосы. Янгынчылык частьләре. Янгынчылык посты*

2) Янгынчы эше. *Янгынчылыкка укыды*

**ЯНДАГЫ** *с.* Янындагы, әйбернең янына урнашкан. *Мин сезнең яндагы йортта яшим.* К.Тимбикова. *Шулай язмышым хәл кылынганны көтеп ятканда, минем яндагы койкага шулай ук күзе яраланган тагын берәүне китереп салдылар.* М.Маликова // Якындагы. *Яндагы урман*

**ЯНДАШ** *с.* **1.** 1) Яндагы, кырыйдагы; эргәдәш. *Яндаш бүлмә*

2) Янга җигелгән. *Яндаш ат*

**2.** *и. мәгъ.* Яндагы кеше. *Яндашларының һәм аркадашларының ышанычлы булуын кайгырт.* Р.Батулла

**ЯНДЫРГЫЧ** *с.* **1.** Яндыра торган, яндыру өчен кулланыла торган. *Дошман фугас бомбалардан тыш бик күп яндыргыч бомбалар да ташлаган икән.* Г.Әпсәләмов. *Тик үзен кулга алды, йөзендә гаепле елмаю галәмәте чагылды, үзе тиз-тиз генә граната һәм яндыргыч шешә хәстәрләде, әзер булса да, нигәдер юанып, нидер көтте.* Х.Камалов

**2.** *и. мәгъ.* Яндыра торган сугыш коралы. *Прицелны җайлап, тиз генә тагы бер яндыргычны аттылар.* Х.Камалов

**ЯНДЫРУ** *ф.* 1) Ут алдыру, ут тергезү. *– Тәмәке тартасызмы, рәхим итегез! – диде дә көмеш портсигарны, шырпыны тоткынга таба этәрде; үзе шуннан папирос яндырып капты ---.* Г.Ибраһимов. *Шәмне яндырып, көрәк белән бер чокыр казыды һәм, кырыкма-*

*са кырык чүпрәккә төреп, акчаларны шунда салып куйды ---.* Ә.Сафиуллин

2) Яктырткыч прибор һ.б.ш.ны эшләтеп җибәрү. *Биктимер фонарь яндыра.* А.Алиш. *Ул, үзе дә сизмәстән, ял бүлмәсенә кереп утны яндырды һәм көзгегә карады.* Ф.Садриев

3) Ут төртеп, нәрсәне дә булса юкка чыгару. *Кемдер, иске чабата яндырып шуның көлен ашасаң, гармунга тиз өйрәнәсең, дип Гатаны ышандырды – Гата анысын да эшләде.* М.Мәһдиев. *Алар безнең кешеләрне үтергәннәр, безнең йортларны яндырганнар.* Н.Фәттах

4) Өтү. *Тиреләрне ваграк кисәкләргә турап, сындырып, йоннарын утта яндырып, тиресен пешерә башладык.* Р.Мингалим

5) Ут ачып, утлы коралдан атып ялкынга күмү; юкка чыгару. *Юлның ике ягында да гитлерчыларның чигенгәндә ташлап калдырган яки качып барганда безнең артиллерия һәм авиация тарафыннан яндырылган, җимертелгән автомашиналары, туплары, арбалары, танклары ауный.* Г.Әпсәләмов. *Мин күпергә җиткәндә, немец самолётлары киткән, берсен безнең зенитчылар яндырган – теге як ярдан кап-кара төтен күтәрелә иде.* Х.Камалов

6) Көйдерү, өлешчә күмергә әйләндерү. *Ул, килеп чыгу белән, чабагачка сапка дип күтәреп кайткан берничә туры, туналган юкә агачларын карт нараткa сөяп куйды да чиләктә быкырдап пешеп яткан боткага карады һәм Рөстәмгә, агайларча: «Бак, ботканы яндырма, берсәк болгап ал!» – диде.* Һ.Такташ

7) Кыздыру, пешерү (кояш нурлары тур.). *Тубал төсле зур кояш түбәдә эленеп тора, рәхимсез яндыра.* Т.Галиуллин. *Кояш яндыра, су, ризык бетә, җәяү китсәләр, барып җитә алмаслар.* Р.Батулла

8) Кайбер нәрсәләрне җитештергәндә, нык булсын өчен, махсус рәвештә ут ярдәмендә эшкәртү. *Әллә әрмәннәрнең башы түгәрәк иде, әллә Айратныкы – кирпечләрне яндырырга мич сыман нәрсә әмәлләп куйдылар.* Ф.Яруллин. *Ул шәһәрләрдә кәрвансарайлар, базарлар, чуен кою, көмеш, бакыр эшкәртү, чынаяк плиткалар яндырып эшләү остаханәләре, кирпеч сугу, сал агызу, йортлар-сарайлар, төрбәләр салу-эшләү Алтын Урданың һәрбер почмагында чәчәк аткан.* М.Әхмәтҗанов

9) Атны озак һәм кызу йөртеп сулыш органнарына зыян салу. *Кайчандыр ярышларда беренчелекне бирмәгән аргамагы Кашка инде картайган, ләкин Җәгүр, Мәскәү кызы утырган поездга җитешер өчен, шул карт алашаны кыйный, яндырганчы чаптыра.* Р.Батулла

10) Өшетеп яисә кызыштырып авырттыру. *Әле генә эчкәнен үзе дә сизми калган аракы дигән шайтан кызның эчен яндыра, миен томалый.* Н.Әхмәдиев. *Әй яндырды, әй өтәләде ул чакта кызыл борыч Газинурның тел очын.* А.Хәсәнов

11) Күзне, тирене зарарлау. *Кояшка күзләрне нәрсә беләндер каплап, яки нәрсәдер киеп карамасаң, ул күзне яндыра.* Уйлар дөньясында

12) Дәвалау өчен биологик тукымаларны лазер белән көйдерү. *Аның тамагын нурлар белән яндырачаклар икән.* Р.Батулла

13) Транспорт чараларын, механизмнарны эшләткәндә нинди дә булса ягулык тоту; ягу (гадәттә, кирәгеннән артык ягу, исраф итү тур.). *Соң, тракторларга электр кирәкми, алар солярка яндыра.* З.Мурсиев

14) *күч.* Зәһәр, ашый торган матдә кулланып зарарлау; бозу, ашату, кистерү; юкка чыгару. *Марганцовка белән яндыргандыр ул аларны.* Р.Батулла. *Калорияләрне яндыру*

15) *күч.* Махсус туклану һәм күнегүләр ярдәмендә организмга кирәксез, артык дип табылган матдәләрне бетерү; юкка чыгару. *Иң беренче, артык май катламнарын «яндырып», фигураны матурлый торган препаратларны бик нәтиҗәле дип мактап тәкъдим итteләр.* Җ.Харисов

16) *күч.* Матди байлыкны әрәм итү, юкка чыгару, кыйммәтен төшерү. *Аз гына хезмәт хакыбыздан салып барган акчабызны да яндырдылар, үз кесәләренә тыгып куйдылар.* Ф.Шакирова

17) *күч.* Кемдә дә булса мәхәббәт хисе уяту; дәртләндерү. *Янган йөрәкне яндырма, Иркенбай.* Г.Сабитов. *Чыгар идем сиңа, артык кайнар бит син, Егеткәем. Яндырырсың, көйдерерсең, пешерерсең, Утка-суга төшерерсең, Ялкыннарың эчерерсең.* Ф.Яруллин

18) *күч.* Берәр төрле көчле хис, уй уяту, борчу, рухи газаплау. *Ничек газапладың син мине, Әнвәр, нинди утларда яндырдың!* М.Маликова. *Эчтә, күкрәкне яндырып, нәфрәт уты дөрли иде.* Н.Гыйматдинова

**Яндыра бару** Булган берсен яндыру. *Бу арада бит очрашканнары да юк, хатларны яндыра барам, ди...* Г.Ибраһимов. *Егерме ике яшемә кадәр язган шигырьләремне яндыра бардым.* Һ.Такташ

**Яндыра башлау** Яндырырга тотыну. *Борыч авызын яндыра башлады Илшатның, күзләрен сөртә-сөртә, икмәк чәйнәргә тырышты ---.* К.Кара

**Яндыра тору** Һаман, булган берсен яндыру. *Кешенең болай да кыска гомерен елларның усал уты, җилле, карлы, сазлы юллары туктаусыз суырып, шәм кебек яндыра тора.* Т.Галиуллин

**Яндыра төшү** Бераз яндыру. *Кухня ягына кереп, әнисе пешереп маташкан коймакны яндыра төшеп, Зөлфия май исе чыгарды, ана моны да сизмәде, күңел күзе белән ул Кәримә кызы белән сөйләшә иде.* М.Хәбибуллин

**Яндырып алу** Бераз яндыру; кинәт яндыру. *Шулай да коры-сары яндырып алу мәслихәт булыр.* С.Шәрипов. *Кызның күзләре егетне яндырып алдылар.* А.Нәҗми

**Яндырып ату** сөйл. Бик тиз арада яндыру. *Бу катализатор айлар, еллар буена установкалардан һавага очып, чәйнекләргә утыра килгән, ниһаять, үткәргечкә әверелеп, линияләрне яндырып аткан иде.* Р.Хисмәтуллин

**Яндырып бару** Булган берсен яндыру. *Минем хатларымны кешегә укытма. Яндырып бар.* Р.Зарипов

**Яндырып бетерү** Барысын да, тулысынча яндыру. *Карамалы урамнарында чаба-чаба, атымны яндырып бетердем ---.* Г.Ибраһимов. *Җылытып кына да калмый, яна-яна, бөртегенә хәтле яндырып та бетерә!* Б.Рәхимова

**Яндырып җибәрү** Тиз генә, кинәт яндыру. *Ләкин бу арада немецлар төрле яктан кибәнне яндырып җибәргәннәр иде инде.* А.Расих. *Берничә егет, куаклар арасыннан барып, иң эре һәм иң бай биш-алты өйне берьюлы яндырып җибәрделәр.* И.Хуҗин

**Яндырып килү** Күптәннән әлегәчә яндырып тору. *Хәзер сиңа сөйләячәк гыйбрәтле вакыйгаларның берсе дә уйлап чыгарылмады, алар инде менә кырык елга якын минем йөрәгемне яндырып килә.* Д.Бүләков

**Яндырып кую** Көтмәгәндә яндыру. *Ишекләрне бикләп, яндырып куюлары да бар, Аллам сакласын.* В.Имамов

**Яндырып ташлау** *сөйл.* Тиз арада яндыру; кызулык, ялгышлык белән яндыру. *Бер каланы яндырып ташлап, аның урынына икенче кирмән төзи башлаган бу кенәзгә безнекеләр Тиле*

*Юрга диган кушамат такты инде.* В.Имамов

**Яндырып тору** Даими яки әледәнәле яндыру; әле, хәзер яндыру. *Беренче сөю чаткылары шулхәтле көчле булды ки, чәчкә чал кергән чорда да яндырып тора.* Ә.Галиева. *Алар балта тотучы, балта чабучылар яныннан йомычкаларны җыеп, утта яндырып торалар.* М.Хәсәнов

**ЯНИЧӘРИ** *и. госм. тар.* 1) Госманлы империясе коралльі көчләренең XIV гасырның икенче яртысында оештырылган һәм солтан Мәхмүд II заманында 1826 елда бетерелгән җәяүле гаскәр төре. *Яничәригә түләнә торган акча*

2) Шул гаскәр төрендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәр, гаскәри. *Төрекчә orta – «яничәриләр полкы» сүзеннән русча рота сүзе килеп чыккан, дигән фикер бар.* Р.Әхмәтьянов

**ЯНИЧӘРИЛЕК** *и. госм. тар.* 1) Яничәри (*2 мәгъ.*) булу. *Яничәрилеге киеменнән үк күренеп тора*

2) Яничәри оешмасы. *Яничәрилекнең төп көчкә әверелүе. Яничәрилекне юк итү*

**ЯНКОРМА** *и.* Бинага өстәп, аны зурайтып үзгәртү һ.б. максат белән салынган корылма; русчасы: **пристройка**

**ЯННАН** *рәв.* 1) Ян-яктан, кырыйдан; читтән, бер кырыйдан. *Егетнең тавышында шундый тирән ышаныч, ныклык бар иде, кыз кинәт тынычланды һәм алдан да, яннан да коеп яуган яңгырга сокланып бара башлады.* А.Гыйләҗев. *Өчесе тиң үзләрен эре бәрәңге ашаган шикелле бик кәттә тоталар, яннан басып күзәткән Нәҗметдин хәтта онытылып, гаҗәпләнеп торды.* В.Имамов

2) Янәшәдән, бик якыннан. *Мин куркырга гына дип торганда, тагын яктырды, һәм бер поезд безнең яннан үтеп тә китте.* А.Алиш. *Безнең яннан, дөбердәп, иләмсез дәү үзбушаткыч узып китте.* А.Гыйләҗев

**ЯНТАЙТУ** *ф.* Нәрсәне дә булса бер якка авыштыру, кыйшайту. *[Подаука] Тулгач – үзенең генә көче җитми – бергәләшеп үлчәүгә асылынабыз, шаугөр килеп, аны янтайтабыз, һәм арбага вак кына җылы бодай ага башлый.* А.Гыйләҗев. *Жуков Антоновка тиз генә карап алды да утырган креслосында гәүдәсен азрак уңга таба янтайтып җайлады, утырырга тәкъдим итмәде.* З.Зәйнуллин

**Янтайта бару** Торган саен янтайту. *Әкрен-әкрен атын бора, ат борылган саен, арбаның алгы тәгәрмәче аскарак кереп, арбаны бер якка янтайта бара.* Ф.Яруллин

**Янтайта бирү** *к.* **янтайта төшү**. *Шул ук мизгелдә көчек, арт ягын янтайта биреп, койрыгын күз иярә алмаслык рәвештә тегеләй-болай болгаштырып, туп кебек дүрт аягында берьюлы сикергәләп, бабайга якынлаша башлады.* З.Зәйнуллин

**Янтайта төшү** Бераз янтайту. *Һәм ул, багор сабын чак кына янтайта төшеп, ыргаклы ягы белән шул тирәне капшый башлады.* М.Хәсәнов

**Янтайтып тору** Даими янтайту; әле, хәзер янтайту. *Каплаган да куйган мин инде: кара кашлар, күзләр, керфекләр, иреннәр, хәтта башын сулгарак янтайтып торулары да минеке ---.* Илһам канатында

**ЯНТАК** *и. бот.* Кузаклылар семьялыгыннан алсу чәчәкле, каты сабаклы, коры далада, чүлдә һәм ярымчүлдә үсә торган күпьеллык ярымкуак үсемлек; дөя чәнечкесе. *Чүл март-апрель айларында гына бераз ямьләнеп ала да, май аенда инде үсемлекләрнең күбесе корып бетә, әйләнә-тирәдә талымсыз саксавыл белән әрсез янтак кына күзгә чалына.* Г.Тавлин

**ЯНТА́У** *и. диал. к.* **янтык** (*1–2 мәгъ.*). *Шулай да күлмәк эченә тулган кылчык, аркаларга, янтауларга кадалып, үрле-кырлы сикертә.* Г.Бәширов. *Менә аңа җиз тәңкәле йөгәнен, түшенә шулай ук җиздән йолдыз ясап куелган янтау каешларын кигездfestлар.* Т.Нурмөхәмметов

**ЯНТАЮ** *ф.* Бер янга авышу, кыегаю, кыйшаю. *[Илсөяр] Аяклары җитмәгәч, каушап, әле уңга, әле сулга янтайды.* Г.Гобәй. *Йөрешеннән танидым: үрдәк кебек, әле бер, әле икенче якка янтаеп атлый.* З.Мәхмүди

**Янтаеп алу** Сизелер-сизелмәс, бераз янтаю. *Аның авыр снарядлары якында гына гөрселдәп шартлаган саен, причал буендагы кораблар, кинәт сискәнеп киткәндәй, бөтен корпуслары белән янтаеп ала иде.* С.Сабиров

**Янтаеп бару** *к.* **янтая бару**. *Әмма ул елдан-ел таушалып, әкренләп бер якка янтаеп бара.* Р.Вәлиев

**Янтаеп бетү** Бик янтаю. *...Иске койма эчендәге җиргә чүгеп, янтаеп беткән йортны аларга байтак эзләп йөрергә туры килде.* Р.Вәлиев

**Янтаеп китү** Кинәт янтаю. --- *Якуп тез белән аның эченә утыртты, яңадан күтәреп алды һәм, урында янтаеп китеп, иңе аша очырды.* А.Хәлим. *Сания күзләрен ачып та җибәрде, көн яктылыгыннан башы әйләнеп, янтаеп та китте.* Г.Гыйльманов

**Янтаеп кую** Кинәт бер тапкыр янтаеп алу. *Өстә калганнар каушаудан кузгалмакчы иде, көймә тагын да янтаеп куйды.* Ф.Баттал

**Янтаеп тору** Әле, хәзер янтайган хәлдә булу. *Куакчыкны арба тәгәрмәче изеп узган, әмма ул әле һаман исән, калкырга маташа, янтаеп торса да, тураерга тырыша.* Безнең мирас

**Янтая бару** Акрынлап һаман янтаю. *Бер якка тәмам кыйшая, читкә янтая барган малайны әнисе шундук күреп алды.* А.Хәлим

**Янтая башлау** Янтаерга тотыну. *Кояш офыкка таба янтая башлагач, Козьма янына Михна килеп җитте.* В.Имамов. *Ерак юлдан хәлсезләнгән гәүдәсен чак-чак өстерәп баручы Нәфисәнең кинәт башы әйләнеп китте, күз аллары караңгыланды, ул бер якка янтая башлады.* Г.Гыйльманов

**Янтая бирү** *к.* **янтая төшү**. *Чыннан да, сул якка янтая биргән гәүдәле кеше Зиннурның әтисе Лотфулла карт иде.* З.Зәйнуллин

**Янтая тору** Торган саен янтаю. *Тиздән газ торбалары да шартлар, ахры, чөнки йорт янтая торгач, алары да бормаланып беткән.* Безнең гәҗит

**Янтая төшү** Бераз янтаю; тагын да ныграк янтаю. *Һашимов, бер якка янтая төшеп, ирengәндәй салмак хәрәкәт белән телефон номеры җыйды.* А.Вергазов

**ЯНТЕРӘК** *и.* 1) Багана, корылма һ.б.ш.ның бер ягына аумасын өчен терәтеп куелган борыс, бүрәнә. *Янтерәккә бәрелү*

2) *күч.* Таяныч, ярдәмче кеше. *Балам – минем янтерәгем.* Әйтем

**ЯНТЫК** *и.* **1.** 1) Кеше яки хайван гәүдәсенең уң яки сул өлеше, ян (*1 мәгъ.*) ягы. *– Телеңне йоттыңмы әллә? – дип, Мәхмүт минем янтыкка төртте.* В.Нуруллин. *Солдатларның иңнәрендә камыт кебек бөтереп төрелгән шинель-скатка һәм авыр карабин, янтыкта кыска саплы җыйнак сапёр көрәге – шанцевый инструмент һәм противогаз савыты.* Р.Кәрами. *Ләкин Габделәхәт, чыбыгын чишеп алып, атның аркасына, арт савырларына да су коя, куллары белән ышкыштыра, һәм менә атның сырты да, янтыклары да бердән ялтырап китә.* Т.Нурмөхәмметов

2) Берәр нәрсәнең уң яки сул яны. *Өстенә озын чабулы күн бишмәт, башына соргылт эшләпә кигән Шәмсүн, янтыктагы ачык тәрәзәдән чәчрәгән тынчу судан сакланмакчы булып, күзләрен чытырдатып йомып, башын аска ишермәкче.* А.Вергазов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Яндагы, ян-яктагы. *Әйткәнемчә, алар ишегалды түрендәге озын гына йортның бер янтык мөешендә, димме, торалар иде.* Ә.Еники

2) Бер якка авышкан, кыегайган, янтайган. *Таҗетдинов герое соры күлмәккә төренгән ябык, янтык гәүдәле, бөкрәйгән ямьсез бер кеше булып күз алдына баса.* И.Илялова

3) Читтә, янда урнашкан. *Болакның бирге ягында, Иске бистәдәге янтык йортларның кыйшык морҗаларыннан һавага туп-туры төтен баганалары күтәрелә.* Ә.Камал

**3.** *рәв. мәгъ.* Янтаеп; яны белән. *[Бу юлы да] ул, бернәрсә исенә төшеп, ана үрдәк шикелле янтык атлый-атлый, ишектән чыгып китте.* Г.Гобәй

**ЯНТЫКЛАЙ** *рәв. диал.* Яннан, янтыктан. *Янтыклай караганда, [шинельле кешенең] яңак чыгынтылары ачык беленмәгән хәлдә, каршылай караганда, алар ачык күренәләр.* Ш.Камал

**ЯНТЫКЛЫЙ** *рәв. диал. к.* **янтыклай**

**ЯНТЫКТАН** *рәв.* 1) Яннан, бер кырыйдан (алдан яки арттан, өстән яки астан түгел)

2) Читтән, ерактан. *Сафа янтыктан моның сүзен бүлде ---.* Ш.Камал

**ЯНУ** *ф.* 1) Ут тәэсиренә бирелү; югары температурада кабынып китү; янучан булу. *Бриллиант утта янмый. Кәгазь тиз яна*

2) Ут эчендә булу, ялкынлану // Ут тәэсирендә юкка чыгу. *Мичкә ташланган соңгы утыннар янып күмергә әйләнде булса кирәк, стенага төшеп торган ялкын телләре уйнаудан туктаган иде инде.* Р.Мөхәммәдиев

3) Мич, учак һ.б.ш. кабызган булу, махсус ягу. *Мич янып бетеп, шау күмер төшкәнче, бер-беребезгә сыенып утырдык.* А.Гыйләҗев. *Бөҗра эчендәге зур мәйданда йөзәрләгән нәни учак яна.* В.Имамов

4) Утлы коралдан атып, утка тотылып, яраксыз хәлгә килү. *Авылга кергән юлда немецларның дүрт танкы янып юкка чыкты.* З.Зәйнуллин

5) Яктылык тарату. *Һәр урынында түгәрәк фонарьлар яна.* А.Алиш. *Хәзер бүлмәдә тоныкөстәл лампасы гына яна иде.* А.Тимергалин // Яктыртып тору, нурлар сибү, балку (кояш, йолдызлар тур.). *Баш очында изгелек билгесе – алтын кояш яна!* А.Гыйләҗев // Җемелдәү. *Аяз төннең зәңгәр күгендә Очкынланып Яна йолдызлар.* М.Җәлил. *Урамда инде караңгы, күктә, чекерәешеп, йолдызлар яна.* А.Гыймадиев // Яктылыгы белән аерылып тору

6) Яктылык тәэсирендә ялтырап күренү. *Мәһабәт төз наратларның очлары ачык яшеллек белән яналар.* Ә.Еники. *Өстәл өстендә сукыр җиз лампа һәм бер почмакта тау итеп өелгән кыйммәтле ташлар ялт-йолт итеп яналар.* А.Гадел // Кояш нуры яки башка яктылык ялкын төсендә күренү. *Шәфәкъ, Мирвәлинең күз алдында янып, сүнеп бетте.* А.Гыйләҗев

7) Кабыну, эшли башлау (приборлар, электротехника тур.). *Менә сигезенче тапкыр чык итте, соңгы сан күренде, һәм... компьютер янә чыелдырга тотынды, мониторда «Код взламывает чужой» дигән сүз янып чыкты.* З.Мурсиев

8) Кабызып куллану мөмкинлеге булу, эшләү (электр, газ һ.б. тур.). --- *тулай торакта кешеләр өчен ут, газ яна, салкын һәм кайнар су килә.* А.Хәлим

9) Электр приборлары, электрлы җиһазлар эштән чыгу, ватылу. *Нәтиҗәдә станцияләрдә трансформатор чорнаулары, хәтта аларның калын бакыр шиннары да эри, кыйммәтле җиһазлар яна һәм сафтан чыга, ә шәһәр энергиясез кала.* А.Тимергалин

10) Авыру яки берәр әгъза ялкынсыну сәбәпле, организмда температура югары булу. --- *мәктәпкә китаплар, күргәзмә әсбаплар алып кайтканда авырый башлый. Мөгаллимнең тәне яна, күз аллары караңгылана, хәле китә.* В.Нуриев // Авырттырып кызышу. *Йөрәк яна, әле авыртып кысыла, әле күзләргә яшь килә.* А.Нәҗми // Бик нык авырту. *Кыйналудан аның тәне яна.* Н.Абделкәримова

11) Эсселәнү, эсседән кайнарлану. *Нинди салкын булсын, эсседән бөтен тәнем яна.* А.Гадел

12) Кызышып китү, кызару. *Фаягөл уйларының чынбарлыкка әверелүен үз күзләре белән күргәндәй булды, битләре кызышып янарга тотынды.* А.Әхмәтгалиева

13) Эшләп яки артык озын юлны кызу үтеп сулыш юллары зарарлану (ат тур.). *Эссе кояш астында бертуктаусыз сабан тарткан ат берзаманны янып егыламы?* В.Имамов

14) Тән пешкәндәге кебек тоелу. *Аяк киемнәре кыса, аркасы кычыта, тамагы яна.* А.Гыйләҗев

15) Кызыштыру, өтү; әчетеп авырту. *Борычтан авыз эче янды*

16) Чи, дымлы булу сәбәпле, бурсып, кызып черү (печән, салам һ.б.ш. тур.). *Ындырда тары яна...* А.Гыйләҗев. *Элеваторда ашлык яна икән!..* Р.Фәизов

17) Кояшта пешеп кызару яки каралу. *Белмәгән кешегә дә әнә көньяк кояшында кызынганы әллә кайдан күренеп тора: бөтен тәне, карасу коңгырт бронза буяу белән буяган шикелле, типтигез булып янган.* В.Нуруллин. *Исмайның, кояшта янып, кыр тузанына каткан каратут йөзе таштан коелган кебек.* Г.Гыйльманов

18) Ут кебек ачык кызыл төсле булу, җетелеге белән күзгә ташланып тору. *Зур кара лаклы тарантаска Газзәбану чәчәкләре янып торган түшәген салды.* Г.Галиева

19) *күч.* Көчле хис тәэсирендә ялтырап тору, очкынлану (күзләр тур.). *Дөнья төзелешен аңлаткан вакытта, Фатиханың күзләре яна, йөзе очкынлана, куллары, тәне хәрәкәткә килә.* А.Нәҗми

20) *күч.* Берәр уй-теләк белән ашкынып, дәртләнеп йөрү; нинди дә булса хис биләп алу. *Безнең дә сез янган теләкләр белән янасыбыз, коллектив алдында эш күрсәтәсебез килә.* А.Алиш. *Я мәхәббәт, я нәфрәттә яныйк, Кирәк түгел гади урталык!* С.Сөләйманова. *Эш кирәк аңа, чын эш!.. Җан азыгы булырдай эш табылса, ул яна, шаша, көя!..* А.Гыйләҗев

21) Ярату, сөю. *Безнең кызларда андый гадәт юк, кыз беренче булып мәхәббәтен белдерә алмый, ул бары тик яшерен янып, яшерен көя генә ала...* Г.Әпсәләмов. *Күзе төште шушы авылның Иң чибәр һәм сылу кызына. Гашыйк булды, янды, көйде, сөйде.* А.Нәҗми

22) Эчтән генә борчылу, үкенү, көнләшү һ.б.ш. көчле хисләр кичерү. *– Ни сөйлисең, әнкәй?! – дип ачыргаланып, янып эндәште ул.* В.Имамов

23) *күч.* Берәр килешмәгән, законсыз һ.б.ш. эштә тотылу, фаш булу. *Миңнулланы алып китеп баручылар: «Булмады, янабыз, ахрысы!» – дип, башта бик каты сүгенешеп алдылар ---.* В.Нуруллин

24) *күч.* Эш үтәлмәү, барып чыкмау. *План шытырдап яна.* А.Гыйләҗев

25) *күч.* Әрәм булу, бушка яки файдасызга китү (акча, байлык һ.б.ш. тур.). *Шактый акчаң янган икән!* А.Гыйләҗев. *Шуңарга ирешә алмый икән, Америкада миллиардлары яначак.* А.Толстой

◊ **Янып тору** Көч, яшьлек дәрте, тазалык сизелеп, аңкып тору. *Кайчандыр ул да Газинур кебек янып торган яшь егет иде.* Г.Әпсәләмов. *Әле моннан бер ел элек кенә янып торган егет ием мин.* В.Нуруллин. **Янып пешү** 1) Эсселәү, тирләп бетү. *Суыта сиңа, мин янып пештем...* А.Гыйләҗев; 2) Кызарып я каралып өлгерү, җитешү. *Үзе ул шундый чибәр, шундый сөйкемле: бит урталары янып пешкән алмадай, күзкашларына шомырт карасы иңгән, куллары шундый йомшак, нәфис ---.* Э.Касыймов

**Яна бару** Торган саен көчлерәк, яктырак яну; һаман яну. *Уятып, уйландырып сез Кәрванны, туганнарым, Яктырак яна барасыз, Юл авыр булган саен!..* Х.Туфан. *Тыштан яна бара, эчтән ит үсә бара.* Х.Камалов

**Яна башлау** Янырга тотыну. *Баеп барган кояшның актык нурлары белән, болытлар алсу кызыл ут эчендә яна башлыйлар.* Г.Ибраһимов. *Бөтен тәне ут кебек яна башлады.* А.Вергазов

**Яна бирү** Бернигә карамый яну. *Тик күктәге йолдызлар гына, бер-берләренә карашып, тын гына яна бирәләр.* А.Нәҗми. *Еллар үтте, Урал ага бирде, Йөрәк яна бирде, Сәбилә.* В.Ильясов

**Яна тору** Туктаусыз яну. *Колга яна тора, киленебез аны эчкәрәк шудыра тора...* А.Гыйләҗев

**Янып алу** Бераз, кыска гына вакыт яну. *Кызның күзләре урынында берничә минут элек янып алган ике күмер кисәге кабат пәйда булды.* Г.Гыйльманов. *Энергияне күп ашамасын өчен, мин аны ун минут эчендә бер минут кына янып ала торган итеп көйләдем.* А.Гыймадиев

**Янып бару** Яна башлау. *Һаҗәр тагы ялкынлана, тагы күзе томанлана, яңаклары кызарып утлана, иреннәре янып бара иде, инде хәлсезләнеп егылам дигәндә, кисәктән сикереп торды да ишеккә йөгерде.* Г.Ибраһимов. *Уң аягының ике бармак арасына кыстырылган газета кисәге инде янып бара иде.* З.Хөснияр

**Янып бетү** Тулысынча яну. *Мичтә утыннар да янып беткән.* М.Гафури. *Ә беренче, матуррак басмасының янып бетмәгән тышлыгын мин учак көле арасында күрдем...* А.Тимергалин

**Янып йөрү** Әле, хәзер яну; озак вакыт яну. *Сине эзләп янып йөрим, Әйталмый теләгемне.* А.Гадел. *Иген әрәм-шәрәм итүгә кайчан чик куярбыз икән дип янып йөрдек.* А.Гыйләҗев

**Янып китү** Кинәт яисә тагын да кызурак яна башлау. *Бибинурның болай да алсу йөзе тагын да янып китте.* А.Гыйләҗев. *Без печән бушаткан арада, самавыр да кайнап чыкты, мунча миче дә дөрләп янып китте.* А.Хәсәнов

**Янып тору** Әледән-әле яну; әле, хәзер яну. *Анда да шулай ук электр янып тора, һәм анда да кешеләр бик күп.* А.Алиш. *Алар да мәк чәчәкләре кебек янып торалар.* И.Нәбиуллина

**Янып утыру** *сөйл. к.* **янып тору**. *Иң элек тәрәзә төбендә янып утырган кып-кызыл яраннарга игътибар итте ул.* Г.Әдһәмова

**Янып чыгу** Ахырда янган хәлгә килү. *Аның коңгырт чәчләре борчак-борчак тир типкән маңгаена сибелгән, яңагы кызарып янып чыккан иде.* А.Вергазов. *Суыткыч янып чыкты, телевизор карамаганга да бишбылтыр инде.* Әгерҗе хәбәрләре

**Янып яту** *сөйл. к.* янып тору. *– Ничек әйтергә дә белмим, Һаҗәр, – диде Мирзаһит һәм Фадеевның Әминәгә язган хаты, Мусаның Берлин төрмәсе ишегалдында янып ята торган кәгазьләр өеме арасында табылган кечкенә запискасы турында сөйләде.* Г.Әпсәләмов. *Төтенсез янып ятабыз Төтәсләнгән дөньяда.* Г.Морат

**ЯНУ́-КӨЮ** *ф.* 1) Эсседән тәмам кибеп, корышып бетү. *Янып-көеп саргылт төскә кергән уңдырышсыз сахрада тереклек бөтенләй юк шикелле, бары үзәнрәк җирләрдә генә ара-тирә ялгызак тут агачлары очраштыргалый.* М.Галәү

2) *күч.* Эсселәү, эсседән кипшенү. *Шунда янып-көеп урак урган чакларда бу күлдә су коенып та бик рәхәтләнә идем.* Г.Ибраһимов. *Арып-талып, янып-көеп, көне буе йөргәннән соң, каяндыр ташлы ярдан бәреп чыккан терекөмештәй саф, боздай салкын суны учың белән алып, чөмерә-чөмерә эчү үзе ни тора!* А.Гыйләҗев

3) *күч.* Борчылу, кайгыру. *Казанга кайтып төшкәч тә Гөлшәһидә, алдан уйлап куйганча, көнозын һәм кич буе гостиницада утырды, менә Мансур килер, менә Мансур килер дип көтте, тәрәзәдән дә карады, коридорга да чыкты – юк, барлык янып-көеп көтүләре бушка булды.* Г.Әпсәләмов. *Мин сокланып, янып-көеп, аның бер җылы сүзе өчен үләргә әзер булып, озак кына аның күзләренә карап тордым.* А.Гыйләҗев // Ярату, сөю. *Бачманның сеңлесе Замирә өчен янып-коя иде бит.* В.Имамов. *Киресенчә, син, түбәнсенүдән дә чирканмыйча, аны фәрештәгә тиңләп, янып-көеп яшәгәнсең.* З.Хәким

**Янып-көеп алу** Бераз яну-көю. *Яшьтәшләренең күбесе беренче мәхәббәт утында мәктәптә укыганда ук янып-көеп алсалар да, Дулкыния үзенең тәүге мәхәббәтен институтта, укытучысына булыр дип һич уйламаган иде.* Г.Бәйрәмова

**Янып-көеп бетү** Тәмам яну-көю. *Әллә инде мәхәббәтебез шул чәчәкләр кебек янып-көеп бетәрме, рәнҗерме?* А.Мансуров

**Янып-көеп тору** Даими яну-көю. *Һәммәсе өчен бертигез янып-көеп торсаң гына дәвалауның шифасы тия.* М.Маликова

**ЯНУТ** *и. рус < гар. зоол.* **1.** Янутчалар семьялыгыннан куе көмешсу коңгырт мехлы кечерәк ерткыч җәнлек; *русчасы:* **енот**. *Янутлар белән бергә монда шулай ук көнгерә, кинкажу да дәвалау курслары уздыра.* Сабантуй. *Аннан соң хәзер ерткыч хайваннарны – төлке, янут мехын бик арзанга гына алгач ауламыйлар.* Шәһри Казан

**2.** *с. мәгъ.* Шул җәнлекнең тиресеннән тегелгән. *Йөри идем мин пух итеп Төлке, янут толыптан, Инде хәзер өтәләндем, Янып чыккан күк уттан.* Г.Камал

**ЯНУ́ТСЫМАН** *с.* Төсе, кыяфәте белән янутка охшаш, шуны хәтерләткән. *Йорт хайваннарыннан – мәчеләр һәм этләр, кыргый хайваннардан төлкеләр, бүреләр, янутсыман этләр һәм төрле кимерүчеләр кешеләргә авыру йоктыручы чыганак булып торалар.* Авыл таңнары

**ЯНУ́ТЧАЛАР** *и. зоол.* Гадәттә, кыска очлыклы янут, какомицли, борынлач, олинго, кинкажуларны берләштергән ерткыч җәнлекләр семьялыгы

**ЯНУЧАН** *с. махс.* Яну үзлеге булган; тиз янып китә торган. *Янучан файдалы казылмаларның дөньядагы запасының күп өлеше биредә тупланган.* Материклар һәм океаннар географиясе. *Кушылмаларның януы оксидлардагы тимер рудасы һәм янучан газлар белән бергә мичкә эләккән һава кислороды исәбенә бара.* Төзү материаллары

**ЯНУЧАНЛЫК** *и.* Янучан булу сыйфаты. *Утка чыдамлык материалның янучанлыгына яки аның кабыну һәм яну үзлекләренә бәйле.* Төзү материаллары

**ЯНЧЫК** *и.* Акча, тәмәке, шырпы кебек нәрсәләр йөртү өчен файдаланыла торган авызы бөрмәле кечкенә капчык. *Кайсы алтын савытларга салынган сигара, кайсы көмеш тартмалардан бармак юанлыгы калын папирос, кайсы атлас янчыклардан мунчала төсле чәбәләнеп беткән тәмәке чыгарып суздылар, ди, батыр егеткә.* А.Алиш. *Акъегет икеләнеп тормый, кесәсеннән алтын тәңкәләр белән янчык чыгара.* А.Гадел

**ЯНЫК** *и.* 1) Берәр нәрсә янганнан сон калган калдык; көек. *Бер читтәрәк тимер-томыр яныклары, шлак өеме ---.* А.Тимергалин // Нәрсәнең дә булса янган урыны; көек

2) Урмандагы янган кишәрлек, янгын урыны. *Анжерка тирәсендәге яныкта котырып куралык үскән, аның җиләген җыеп бетерә торган түгел иде ул елны.* Ш.Маннур

3) Урманны яндырып эшкәртелгән иген кыры; ышна. *Басу түрендәге яныкта ук урып ята идек.* Ш.Маннур

**ЯНЫНА** *бәйл.* 1) Эш-хәрәкәтнең башкарылуы берәр предметка, затка юнәлүен, шуның кырыена, тирәсенә тупланауын күрсәтү өчен кулланыла. *Савыт-сабаны җыештыргач, өстәл янына килеп утырып, гадәтенчә ашыкмыйча сөйләвен дәвам итте ---.* С.Сабиров. *Мин уяну белән сикереп тордым да тышка, таш сын янына йөгереп чыктым.* Г.Рәхим

2) Берәр предметның нәрсә беләндер бергә, шуңа өстәп, кушып бирелүен белдерү өчен кулланыла. *Әни исә, матурым, зур кыюлык белән: «Алайса, чәй янына мин төче коймак пешереп бирәм», – диде.* А.Хәсәнов

**ЯНЫНДА** *бәйл.* Эш-хәрәкәтнең берәр предметның, затның, урынның кырыенда, тирә-ягында башкарылуын белдерү өчен кулланыла. *Агач астына туарылып куелган арба янында, күләгәдә, чал кергән кәҗә сакаллы Гайнулла карт, җиргә тезләнгән көе, чәкчәк килеп чалгы таптап утыра иде.* Н.Фәттах. *Йортлары янында авылда беренче булып агач бакчасы ясап, карлыган, кура, чия, алма, крыжовниктан җиләк-җимеш җыеп алучылар да, алардан варенье диган татлы ризык әзерләүчеләр дә Әмин абый гаиләсе булды.* Т.Нәҗмиев

**ЯНЫННАН** *бәйл.* Эш-хәрәкәт берәр зат, предмет, урынның кырыеннан, тирәсеннән юнәлеп, үтеп башкарылуын белдерү өчен кулланыла. *Мәктәп яныннан узганда, тәҗрибә бакчасында мәш килгән классташ кызлар кызыгып карап калдылар.* А.Тимергалин. *Авыл яныннан Кече Чирмешән елгасы ага.* Ф.Гарипова

**ЯНЫП** *рәв.* Көчле хис белән, дәртләнеп, кызып-кызып. *Мин бер сәгать буе аның белән янып бәхәсләшеп утырдым.* Ш.Маннур

**ЯНЫ́П-ПЕШЕП** *рәв.* 1) Эсселәнеп, тирләп. *Кояшта янып-пешеп, йөзем лапасы астындагы күләгәдә бераз җиләслек алырбыз дип ихатага аяк басу белән, туганнарыбызның кайнар кочагына килеп кергәндәй булдык.* А.Хәлим. *Печән өсте дисеңме, әллә урак өстеме, янып-пешеп, сусап, шул кизләү суы аккан улакларга ятып эчкәндә дә ул су тамакка тими, сусауны баса.* Ә.Салах

2) *күч.* Бик тырышып, бөтен көчне куеп. *Төзәтәбез янып-пешеп, Ялгыш язган сүзләрне без Үзгәртәбез тиргә төшеп...* Р.Миңнуллин

**ЯНЬЧЕК** *с.* 1) Яньчелгән. *Мәдрәсәдән Кабан күленә төшә торган сукмак буйлап кулларына яньчек комган тоткан, иңбашларына сөлге салган шәкертләр тыз-быз йөреп торалар.* М.Галәү. *Гани, яньчек эшләпәсен кырын салып, тасраеп-тасраеп карап торды аңа.* С.Зыялы

2) Җәенке һәм тупыйк формадагы. *Мин гомерем буе шушы яньчек борыным өчен хафаландым.* Р.Батулла

**ЯНЬЧЕЛҮ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **яньчү**. *Яньчелгән, тутык баскан вагонеткалар тәмам алҗып беткәннәр сыман...* Ш.Рәкыйпов. *Күпер киң, унбиш-егерме адым озынлыкта, ике ягында нык тимер култыксалар, бер урында яньчелгән – машина яки трактор бәреп киткәндер.* Р.Кәрами // Изелеп формасы бозылу. *Автобус бистәгез кырыеннан гына уза икән, сезгә хәтле җәяү тәпили-тәпили үкчәм яньчелде.* Н.Гыйматдинова

2) Бәрелеп, егылып, берәр нәрсә астында калып, кысылып зарарлану, имгәнү. *Әмма бер кулы яньчелгән бала Рөстәм булып чыкмады.* Г.Кутуй. *Барак ишеге төбендә аны күкрәгенә яшел өчпочмак теккән, борыны яньчелгән бер кеше туктатты.* Г.Әпсәләмов

**Яньчелә төшү** Бераз яньчелү; тагын да ныграк яньчелү. *Кыршылган фәс тагын да яньчелә төшкән кебек була, хәзрәтебез үзе дә йолкынган әрекмәндәй шиңеп китә.* Г.Гобәй. *Гасыйм Сәлахович кыска җиңле саргылт күлмәген, яньчелә төшкән капрон эшләпәсен киеп һәм биге бозык иске зур портфелен күтәреп өеннән чыкканда, сәгать ун тулып килә иде инде.* Ә.Еники

**Яньчелеп бетү** Бик нык яньчелү; берничә урыннан яньчелү. Карт өстәлгә *корымга каткан чәйнек белән кайнар су, яньчелеп беткән ике кружка китереп куйды.* Г.Әпсәләмов. *Менә аның хатыны Әнисә, төбе яньчелеп беткән коштабак тотып, келәт каршында басып торадыр.* В.Имамов

**Яньчелеп киту** Кинәт яньчелү. *Яньчелеп үк китте чиләге.* В.Нуруллин

**ЯНЬЧҮ** *ф.* 1) Кысып, таптап, изеп, бәреп, баскалап, нәрсәнең дә булса берәр җирен эчкә батыру. *Әле бит син белмисең: шабашка эшләгәндә берәүнең иномаркасын яньчедем уголоклар белән – аңа биш мең доллар түлисе бар.* З.Хәким // Гомумән формасын бозу

2) *күч. сир.* Рухи яктан сындыру; газаплау. *Ялгызлык адәм баласын изә, яньчи, котырыну чигенә җиткерә икән.* С.Поварисов

**Яньчеп алу** Тиз генә яньчү. *Яньчеп кенә алды чүкече!* Ф.Яхин

**Яньчеп бетерү** Бөтенесен яньчү; күп урыннан яньчү. *Бөтен чиләк, ләгәннәрне яньчеп бетерде.* М.Галәү. *[Минем самавырымны] сезнең асраулар үзләре өчен куеп яньчеп бетерделәр.* Ә.Фәйзи

**Я́Н-ЯК** и. 1) Пространствода уң яки сул як. *Хәзер инде колоннаны нибары дүрт сакчы саклап бара иде: берсе – алда, икесе ян-якларда, дүртенчесе арттан атлый.* Г.Әпсәләмов

2) Гәүдәнең җилкәдән алып янбашка кадәр уң яки сул ягы; янтык. *Аркасында, ян-якларында капчык, кулында таяк.* А.Гыйләҗев

3) *к.* **тирә-як**. *Ян-якка, әйләнә-тирәгә нинди тәмле әчкелтем ис тарата.* А.Хәсәнов

**ЯҢА́** *с.* **1.** 1) Әле генә эшләнгән, ясалган; хәзер генә алынган; бер дә тотылмаган. *Әйтик, ни өчен ул яңа телевизор, яңа палас, бигрәк тә яңа карават алып бирү хакында үзе уйлый белми?!* Ф.Баттал. *Яңа күн итегенә яңа кием шулкадәр килешеп тора иде.* Г.Гыйльманов

2) Элек булмаган, яшәмәгән, күптән түгел килеп чыккан, төзелгән, күренгән. *Яңа өй җиткереп кердем.* А.Гыйләҗев. *Яңа юл салдылар*

3) Күптән түгел ачылган, уйлап табылган. *Болар яңа дару-препарат уйлап тапканнар, ә баш редактор, яңалыкны тизрәк эләктереп, үз гәзитәсендә шаулатмакчы икән.* Н.Гыйматдинова. *Галимнәр яңа вакцина уйлап тапты.* Мәйдан

4) Элек булмаган, соңыннан китереп чыгарылган (токым, сорт һ.б.ш.). *Бу аланга колхоз, орлыклык өчен, көздән яңа сорт арыш чәчәргә исәпли иде.* Г.Әпсәләмов. *Кайчандыр селекционерлар, көтүдә кып-кыска, аеры аяклы сарык бәрәннәре тугач, шуларны кушылдыру юлы белән, тәбәнәк кенә киртәне дә сикереп үтә алмый, ягъни кача алмый торган яңа токым сарык чыгарганнар.* А.Тимергалин

5) Күптән түгел басылып чыккан, язылган. *Яңа китап чыккан, алдыгызмы?* Г.Исхакый

6) Таныш булмаган, моңарчы билгеле булмаган. *Бернichә тапкыр дивизия бөтен составы белән яңа урынга күченде, аннары аны эшелоннарга төяделәр дә каядыр көньяк-көнчыгышка таба алып киттеләр.* Г.Әпсәләмов. *Шобага салгач, Тиррен җитәкчелегендәге лидлар, ватаннарын ташлап, яңа җир эзләп китәргә мәҗбүр булалар.* Н.Фәттах

7) Күптән түгел таралган, искереп өлгермәгән; әлерәк ишетелгән. *Кыз егеткә яңа хәбәр җиткерде.* А.Гыйләҗев

8) Күптән түгел килгән, эшкә алынган, укырга кергән һ.б.ш. *[Самат:] Сез, Кәрим, бирегә яңа кеше.* А.Гыйләҗев. *Рухия – хәйләкәр кыз! – хаклы булып чыкты: Валентин Иванович класста яңа укучы барын бөтенләй сизмәде.* В.Нуруллин

9) Элекке урынына чыккан, килгән, алдагысын алмаштырган. *Больницага бүген Казаннан яңа мөдир килергә тиеш.* Һ.Такташ. *Яңа укытучы утырган хәлендә, кузгалмыйча, алдында утырган укучыларны карый башлады.* З.Зәйнуллин

10) Элек татылмаган, моңа кадәр кичерелмәгән. *Аларны тәрбияләп, яңа тормыш өчен көрәшүче батырлар тудыру – бу безнең бурыч!* А.Алиш. *Чөнки туйдан соң яңа тормыш башлана.* А.Нәҗми

11). Агымдагы елдагы, быелгы (уңыш тур.). *Җәй буе борчак, яңа бәрәңге, әвендә киптерелгән, төтен тәме сеңгән яңа арыш умачы ашап, капчык күтәреп тән ныгып беткән – бүген әнә шул көчне кая куярга белгән юк.* М.Мәһдиев. *Менә шул: яңа уңыш оныннан сөтле умач пешерү йоласы, Әнисәгә ияреп, Болгариядән килгән булган.* Г.Гыйльманов

12) Чагыштырмача күптәнгә булмаган чорга, эпохага караган; Урта гасырлардан соң килгән. *Яңа заман башында әле Европада күп кенә дәүләтләр ниндидер бер милләткә нигезләнеп формалашканда, кайбер мәмләкәтләр элеккечә Урта гасырлардагы династия принцибы буенча барлыкка киләләр.* Яңа заман тарихы

**2.** *и. мәгъ.* 1) Моңарчы булмаган әйбер, күренеш һ.б.ш. турында. *Элекке мәктәбемдә дә шулай булды, яңасына күчкәч, Руслан белән аралашып китүем дә үземне бүлдерми генә тыңлый белүче табылудан иде, ахры.* А.Әхмәтгалиева. *Бер-ике көн элек бөтенләй башка циклон иде, ул көнбатышка китте, аның урынына Самарадан яңасы килде.* Хезмәт даны

2) Быелгы, алдагы уңыш. *Атым, сыерым, сарыкларым һәм яңага хәтле җитәрлек икмәгем бар.* Ш.Камал. *Бәрәңгене яңага җиткерү. Яңа җиткәнне көтү*

3) Яңалык. *Озак та үтмәде, хәбәрнең яңасы килде: Минзәләдә яшәп ятучы кырык бер яшьлек Саттар Гаттаров очачак икән!* Ф.Баттал

**Я́ҢА** *рәв.* Әле генә, күптән түгел. *Яңа сакал чыккан яшь кенә бай әрлебирле йөри.* М.Гафури. *Яңа гына Миргарифҗан малаеннан хат килгән.* Т.Гыйззәт

**Я́ҢАБАШТАН** *рәв.* 1) Өр-яңадан, бөтенләй үзгәртеп. *Аннары тоткыннарны яңабаштан сафка тезәргә тотынды, ыгы-зыгы килде, кычкырынды, сүгенде.* Г.Әпсәләмов. *Хәлимгә һәр эшкә яңабаштан өйрәнергә туры килде.* Г.Гыйльманов

2) *к.* **яңадан**. *Без тагын да бөтенесен яңабаштан башлыйбыз булып чыга.* Б.Рәхимова

**Я́ҢАДАН** *рәв.* Тагын, тагын бер мәртәбә. *Габдерахман, серле елмаеп, сандыкларны җиңел генә берәм-берәм яңадан ачып күрсәтә.* А.Гадел. *Кыз, карашын яшереп, яңадан агымсуны күзәткәндәй итте.* А.Нәҗми

**ЯҢАДА́Н-ЯҢА** *с. арт. дәр. к.* **яңа**. *Бигрәк тә шуларның мәктәп яшендәге балалары айдан төшкәндәй кыландылар: яңадан-яңа күлмәкләр, бармакларда-колакларда алтын да якут, ә Фәридәнең кызы шул хәреф тә танымаган катыборыннар арасында ел башында алынган күлмәген киеп йөри, тегеләрнең мыскыллы сүзләрен күтәрә – егылып үләрсең.* К.Кара

**ЯҢА ЕЛ** *и.* Беренче январь көне; елның башлануына багышланган бәйрәм. *Кече кызым Гүзәл Яңа ел алдыннан гына уникe кадак авырлыктагы тагын бер малай алып кайтты.* А.Хәсәнов. *Яңа ел мәҗлесе бик күңелле башланды.* А.Расих

**ЯҢАК** *и.* 1) Йөзнең колак төбе, авыз чите һәм күзнең тышкы почмагы арасындагы өлеше, битнең ян ягы. *Муса әнисенең кытыршы кулын тотып, мендәр итеп, яңагы астына куя.* Г.Әпсәләмов. *Нуровның борын канатлары кабарды, яңак төерләре уйный башлады.* А.Тимергалин

2) Ишек һәм тәрәзә уемының ян ягына утыртылган борыс. *Моңарчы абайламаган идек: ишек яңагы янында стенада телефон бар икән, фельдшер апа шалтырата башлады.* А.Гыйләҗев

◊ **Яңагына менеп төшү** *к.* **яңаклау**. *Хәтмулла да бернichә тапкыр Фатыйманың яңагына менеп төште.* М.Кәбиров. *Фрося йомшак учы белән тиз генә ирнең яңагына менеп төште.* Ф.Бәллүр. **Яңагына берне утырту** *к.* **яңагына менеп төшү**. **Яңагыннан ут чыгару** Яңагына каты итеп сугу. *[Анна:] Яңагыннан ут чыгардыңмы*? А.Гыйләҗев. *Сәриманең кайтканын капка төбендә саклап торды да, кызы капка төбенә килеп җиткәч, яңагыннан ут чыгарып чалтыратты.* Д.Каюмова. **Яңагы суырылу** Бик ябыгу. *Гәрәй Рәхимне танырлык та түгел: Хиросима бомбасыннан исән калган кеше кебек, яңагы суырылып калган.* М.Галиев. **Яңагы эчкә бату** *к.* **яңагы суырылу**. *Тик бик аз вакытка, Мөбарәк остазының хәлсез, алҗу, ике яңагы эчкә баткан ябык йөзен күреп хәйран калды.* С.Поварисов. *Яңагы эчкә баткан, күптән кырыну күрмәгән ирнең иңнәрендә иске куртка.* З.Мурсиев. **Яңагы яңакка ябышу** *к.* **яңагы суырылу**. *Гаскәри форма эчендә, бигрәк тә шинеле эчендә үзе дә шылтырап йөрерлек, яңагы яңакка ябышкан әтине, беренче Герман сугышында мылтык та тотып караганы бар икән дип, теплушка вагонга төяп, туп-туры фронтка алып киттеләр.* Т.Нурмөхәммәтов

**ЯҢА́К КАЛКЫМЫ** *и. анат.* Яңак сөягенең күздән түбән калкып, чыгынкыланып торган өлеше; *русчасы*: **скула**. *Яңгураның уң яңак калкымы бии башлады.* Г.Әпсәләмов

**ЯҢАКЛА́У** *ф.* Кемнең дә булса яңагына уңлап-суллап сугу, яңагына чабу. *Әнисе аны яңаклый-яңаклый аңына китерергә тырышты.* З.Кадыйрова

**Яңаклап алу** Бер яки берничә мәртәбә яңаклау. *Елап, шешенеп беткән хатыны Лена аны килеп кергән шәпкә яңаклап алды.* З.Мәхмүди. *Ә аның күз агын күрсәтеп акайган күзләре, профессорны шул арада яңаклап алгандай итеп, уңлы-суллы йөгерә бирәләр.* Ф.Яхин

**Яңаклый башлау** Яңакларга тотыну. *Мин дә читтә кала алмадым, шул бәргәләшнең эченә кереп, уңга-сулга яңаклый башладым.* Г.Ибраһимов

**ЯҢА́К СӨЯГЕ** *и. анат.* Баш сөягенең яңак турысындагы сөяге. *Шушы берничә сәгать эчендә ул күзгә күренеп ябыкты: күзләре батып, күз төпләренә күләгә төште, яңак сөякләре калыкты, ике каш арасындагы сызыгы тирәнәйде.* И.Гази

**ЯҢАК ЧЫГЫНТЫСЫ** *и. к.* **яңак калкымы**

**ЯҢАЛИФ** *и.* Латин алфавиты нигезендә төзелеп, 1929–1939 елларда кулланылышта булган яңа татар язуы. *Мин үзем яңалиф белән генә укыган.* Г.Камал

**ЯҢАЛИФЛӘШТЕРҮ** *ф.* Татар графикасын яңалифкә күчерү, яңалиф алфавитына яраклаштыру. *Яңалифләштерү еллары*

**ЯҢАЛИФЛӘШҮ** *ф.* Гарәп язуыннан яңалифкә күчү, латин алфавитына күчү. *Ун ел буена яңалифләшкәч, безне кабат, мәҗбүриләп, инде кириллицага керттеләр, христианнарга «якынайттылар».* Татарстан яшьләре

**ЯҢАЛИ́ФЧӘ** *рәв.* Яңалиф алфавиты белән. *[Камил (Алекка):] Син яңалифчә укый алмыйсың ич.* Һ.Такташ. *Биш яшемдә гарәпчә, русча, яңалифчә хәреф таный башлаганлыктан, чормадагы китаплар арасында мин рәхәтләнеп утыра идем.* М.Мәһдиев

**ЯҢАЛИФЧЕ** *и.* Яналиф тарафдары, яңалифләшү яклы кеше. *[Вәли:] Дәдәң хәзер яңалифче инде.* Г.Кутуй

**ЯҢАЛИФЧЕЛЕК** *и.* Яналифне яклау (юнәлеше). *Яңалифчелек сәясәте*

**ЯҢАЛЫК** *и.* 1) Яңа булу сыйфаты. *Күлмәгенең яңалыгы күренеп тора*

2) Нинди дә булса яңа нәрсә. *Аның каравы Әбүзәр абзыйның кабинетына әллә ни яңалык кертеп булмады.* Г.Әпсәләмов. *Фәнни яңалыклар*

3) Күптән түгел алынган яки күптән түгел билгеле булган хәбәр. *Юл төзүчеләр түбән очтан асфальт җәя башлыйлар – яңалык менә шул.* А.Гадел

4) Элек булмаган күренеш, яңа тәртип, яңа ысул, яңа гадәт һ.б.ш. үзгәрешләр. *Әлеге вакыйга – татар әдәбияты өчен дә тиңе булмаган зур яңалык.* В.Имамов

5) Яңа тормыш; яңа карашлар; прогресс. *Хәзер яңалык вә искелек низаглары чалбар балагыннан, мыектан үтеп бара.* Г.Ибраһимов

**ЯҢАЛЫКЧЫ** *и. к.* **новатор**. *Л.Т.Мәхмүтова фәнни тикшеренү ысулларында кыю яңалыкчы булды.* Фән һәм тел

**ЯҢАЛЫКЧЫЛЫК** *и. к.* **новаторлык**. *Фәндәге яңалыкчылык*

**ЯҢАРАК** *рәв.* Бая гына, әле генә. *Яңарак кына кайтып кердем*

**ЯҢАРТУ** *ф.* 1) Яшәп килгән тәртипне һ.б. үзгәртү, яңача эш итү. *Озын Куакта һөнәрчелекне яңартып җибәргәннәр.* Г.Шәйхи. *Инде күргәнегезчә, «Татарстан», «Сөембикә», «Ялкын» журналларының да эчтәлеге, тышкы, эчке бизәлеше һәм дизайны тулысынча яңартылды.* Г.Шәйхи

2) Искергән, таушалган, бозылган нәрсәне элекке хәленә яки гомумән нормаль хәлгә китерү, төзәтү. *Билгеле, иярне кат-кат төзәтеп, киезләрен генә түгел, арчагын да яңартканнар.* А.Тимергалин. *Мәктәбен тәмамлыйсы елны әтисе белән йорт тирәсе рәшәткәләрен яңарттылар.* А.Хәйретдинова

3) Өс киеме, җиһаз турында: яңага алмаштыру. *Шулай булмыйча, бик сагынып көткән иде ич: ул яраткан ризыкларны пешертте, урын-җирләрне яңартты.* М.Әмирханов. *Практикалары өчен яхшы түлиләр икән: Дима кай арада киемнәрен яңартты, үзенә, тотылган булса да, машина алып җибәрде.* Р.Габделхакова

4) Туктап торган, өзелгән һ.б.ш.ларны торгызу, дәвам итү

5) Онытылганны искә төшерү һәм яңаны өстәү. *Имтиханга әзерләнгән көннәрдә дә берничә тапкыр кабатлап, хәтердә яңарткан идем мин аны.* В.Нуруллин. *Хуҗа, горурланып, артист яшьтәшенең малай чактагы гадәтләрен искә төшерә, балачак хатирәләрен яңарта.* Г.Гомәр

6) *күч.* Рухи баету, сафландыру. *Юньле карт булсаң, үз гөнаһыңны үзең белеп, иманыңны яңартып, түр башында гына утырыр идең син*! Г.Бәширов

7) *күч.* Элеккеге кичерешләрне кабат кузгату, искә төшерү. *Яңартмаска булдым үткәнне.* Г.Морат

8) Мич, мунча, самавыр һ.б.ш. турында: кабат ягып, өстәп, яндырып кайнарлау, җылыту. – *Әйдәле, Сәрия багалмам, өйгә уз әле, хәзер самавырымны яңартам, бәйрәмчә табын әзерләрбез! – дия-дия, Хөршидәттәй чак кына тартынып торган Сәрияне, җитәкләп, өйгә алып кереп китте.* А.Тимергалин. *Утын өстәп, учакны яңарталар.* А.Гадел

9) *күч.* Кабат кайту, дәвам итү, ялгап җибәрү (сүз, фикер тур.). *Кичке якта чишмә буена җыелган хатыннар тагы шул турыда сүз яңарттылар.* Н.Кәримова. *Башкача бу темага сүз яңарткан булмады.* Кызыл таң

**Яңарта башлау** Яңартырга тотыну. – *Чигенгән чакта булды бу хәл, – дип, Гыйльметдин бабай хәтердәге вакыйгаларны яңарта башлый.* Ф.Яруллин. *Аннан күреп, булдыклырак авыл агайлары да каралты-кураларын яңарта башлыйлар.* Р.Вәлиев

**Яңарта төшү** Бераз яңарту. *Ул киемсалымын яңарта төште*

**Яңартып алу** Кыска гына вакытта яңарту. *Композитор истәлекләрен яңартып алды.* Г.Гомәр

**Яңартып бирү** Башка берәүгә яңарту. *Ахирәтләренең кием-салымнарын яңартып бирә.* Кызыл таң

**Яңартып җибәрү** *к.* **яңарта башлау**. *Кем килеп керсә дә, үз туганы килеп кергән шикелле куанып, самавырын яңартып җибәрә.* В.Нуруллин

**Яңартып тору** Даими, гел яңарту; әле, хәзер яңарту. *Шәһәрләрдә фонтаннардагы суны да һаман саен яңартып торалар бит.* Г.Әпсәләмов. *Күңеле пакь инсан өстендәге күлмәген дә гел яңартып тора.* В.Имамов

**ЯҢАРУ** *ф.* 1) Искесе яңага алмаштырылу. *Ак калфагың яңарган, яңарса да, каралган.* Гали Рәхим. *Яшеештә бар да үткән, Киемнәр дә яңарган.* К.Булатова

2) Искергән, тузган нәрсә элекке хәленә кайту, баштагы төсен алу яки яңарак, нормальрәк төскә, кыяфәткә керү. *Парик асларында чәч яңарды.* И.Гыйләҗев

3) Яңартылу, төзәтелү; һәртөрле искелектән котылып, бөтенләй яңа төс алу. *Кызыл Октябрь урамы бөтенләй яңарган икән хәзер.* А.Тимергалин

4) Сафлану, рухи баю; заманчалашу, яхшы якка үзгәрү. *Чибәркүлгә ак күлмәк киеп кайтырлык булгач, күңеле яңарган инде аның, сиңа әйтәм.* А.Гыйләҗев. *Ул чаклардан бирле сөю хисе Тагын сафлангандыр, яңарган.* Н.Әхмәдиев

5) *күч.* Кабат кузгалу, тергезелү. *Яңарган азаннар – милләтнең Үткәнен, иманын саклавы.* М.Шиһапов. *Ул алтмышынчы елларда яңарган иректе шигырь алымы белән язылган, шул сәбәпле дә чор өчен яңалык буларак бәяләнгән.* Р.Рахман

6) *күч.* Кабатлану, кабат-кабат эшләнү; искә төшү. *Кинәт Мирвәлинең хәтерендә бүген генә Гаделгә сөйләгән легенда яңарды.* Г.Гыйльманов. *Сания әбинең күңелендә балачак хатирәләре яңарды.* А.Фәләх

7) *күч.* Сүз, фикер турында: ялгану, дәвам ителү. *Чәй вакытында әңгәмә тагын яңарды*

**Яңара бару** Торган саен яңару. *Гарәп поэзиясе әкренләп яңара бара.* К.Гыйззәтов. *Андамыни хикмәт, иң әһәмиятлесе – яшәү, тормыш яңара бара-бара дәвам итә һәм итәчәк бит!* Ф.Яхин

**Яңара башлау** Яңарырга тотыну. *Төш җиткәндә, буа күзгә күренеп яңара башлады.* К.Тәхау. *Факиһә самавыр башындагы чәйнекне чак кына кыйшайтып куйды: самавыр, болындагы чиллә чикерткәләре авазы чыгарып, яңара башлады.* Р.Батулла

**Яңарып кую** Кинәт, көтмәгәндә яңару

**Яңарып тору** Даими, гел яңару; хәзерге вакытта яңару. *Сый артыннан сый яңарып торды, табын озак барды.* В.Имамов. *Интернетта вируслар яңарып тора.* Д.Шәйхетдин

**ЯҢАРЫШ** *и.* 1) Берәр нәрсәнең тукталып торган яшәеше кабат кузгалу күренеше; таркалу, җимерелүдән соң күтәрелеш. *Инде үзебезнең туган авылыбыз йөзенә дә зур яңарыш кертәсебез килә.* В.Имамов. *Авыл кабат яңарыш чоры кичерә.* Г.Шәйхи

2) *к.* **ренессанс**. *Тагын да ераккарак кайтыйк: итальян скульпторы, коючы, алтын эшләре остасы Лоренцо Гиберти (1381–1455) Яңарыш сәнгатенең беренче тарихын яза, бу «Комментарийлар» өч китаптан тора икән.* М.Хуҗин

**ЯҢА́ЧА** *рәв.* **1.** 1) Яңа ысул, алым белән; берәр яңалыкка нигезләнеп. *Зәбихулла абый, үзе кадим мәдрәсәсендә укыган кеше булганлыктан, яңача укытуны белеп җиткермичә, кайчакларны, күрәсең, кадимен-җәдитен бергә бутап та укыткандыр.* Г.Бәширов. *Эштә инициатива, эшне яңача оештыру аеруча хуплана башлады.* В.Нуруллин

2) Хәзерге заманча, хәзерге заманга туры китереп. *Нургалиемнең, авылга кайтып, яңача яшәү хыяллары да бар.* Г.Галиева. *Булачак сәләтле инженерлар, табиблар, укытучылар, галимнәр – киләчәктә туачак яңа техника, технология, яңача дәвалау һәм белем бирү, яңа ачыш авторлары.* Н.Шәрифуллин

3) Яңа төрле итеп, башкача. *Үзе таптаган басуларны ул бүген яңача күрә.* М.Хуҗин

**2.** *с. мәгъ.* Яңа, яңа булган. *Мәсьәләгә яңача караш*

**ЯҢГЫР** *и.* 1) Атмосферадагы су парының авыраюы белән барлыкка килгән, җир өстенә ява торган явымтөшемнең су тамчылары рәвешендәге төре. *Көндез бераз яңгыр сибәләп узганлыктан, урамда яңгырдан соң гына була торган җәйге саф һава.* А.Гыймадиев. *Моңа тикле бер атна тоташ яңгыр койды.* А.Хәсәнов

2) *күч.* Күпләп коела, сибелә, чәчелә торган берәр нәрсәнең ташкыны. *Сугышчыларга каршы кургаш яңгыры ява башлады, сазлыкның пычрак суын актарып, миналар ярылырга тотынды.* Г.Әпсәләмов. *Алар өстенә агач аралырыннан ук яңгыры сибелде.* Р.Сәгъди

**ЯҢГЫРАВЫК** *и.* **1.** *к.* **кайтаваз**. *Таулар арасыннан яңгыравык кына ишетелде*

**2**. *с. мәгъ. к.* **яңгыравыклы**. – *Тыңлагыз, сезгә сүзем бар!* – *дип кычкырды Тотыш, көр, яңгыравык тавыш белән.* Н.Фәттах. *Шунысы сокландыра: куллары, гәүдәләре өзлексез хәрәкәттә булса да, алар бер-берсе белән гәпләшәләр яки кумәкләшеп җыр сузалар – чишмә чылтыравы кебек дәртле, яңгыравык авазлары ишетелә.* Р.Кәрами

**ЯҢГЫРАВЫКЛЫ** *с.* Яңгырап торган. *Кинәт аралашу юлларында почтальон Зиманың яңгыравыклы күңелле тавышы ишетелде.* Г.Әпсәләмов

**ЯҢГЫРАТУ** *ф.* 1) Тирә-якка көчле, яңгыравыклы аваз тарату; кайтаваз, шаукым тудыру. *Урамнан узган арбаның дөбердәве бөтен авылны яңгырата.* Г.Бәширов. *Солдат итекләре идәнне яңгырата, егетләр читтән генә көч биреп тора.* Р.Газизов

2) Көчле яңгыравыклы тавыш чыгарып уйнау яки җырлау. *Алда өсте ябулы, ярымтүгәрәк түбәле сәхнә, анда симфоник оркестр урнашкан: төрледән-төрле инструментларның тигез матур авазлары кичке тынлыкны яңгырата.* Р.Кәрами

3) Тапшыру, уйнату. *Музыкаль әсәрне беренче кат радиодан яңгырату*

4) *күч.* Бик киң таралу, билгеле булу (дан, исем һ.б.ш. тур.). *Аның ачышы дөньяны яңгыратты*

**Яңгырата башлау** Яңгыратырга тотыну. *Радиодан мин яраткан җырны яңгырата башладылар*

**Яңгыратып тору** Гел, әледән-әле яңгырату; хәзерге вакытта яңгырату. *Сабый йөзле, ябалак кыяфәтле бу кошлар, бер-берсе белән куышып очып йөргән вакытта, шомлы тавышлары белән бөтен Тын елгасын яңгыратып торалар икән.* Г.Гыйльманов

**ЯҢГЫРА́У** *ф.* **1.** 1) Металл тавышына охшаган көчле, кайтавазлы ачык тавыш чыгару. *Пычкы чыжлап кискән, барабан суккан тавышлар яңгырый.* А.Гадел

2) Ачык ишетелү, таралу. *Сихри музыка яңгырый.* А.Гадел. *Биек тау башыннан, тарлавыклар буйлап яңгырап, дәрвишнең тавышы гына кешеләргә төшеп ирешә.* Р.Батулла

3) Хәтердә булу, онытылмау, һаман ишеткән кебек истә тору. *Һәркемнең башында вожатыйның соравы яңгырый.* А.Әхмәт

4) *күч.* Нинди дә булса тәэсир калдыру. *Көнбатыштан килгән Марсель исеме горур яңгырый.* А.Тимергалин

5) *күч.* Танылу, исеме таралу, билгеле булу. *Ләкин Дасаев, Һидиятуллин, Нигъмәтуллин кебек фамилияләр бөтен дөньяга яңгырады.* Казан утлары. *Безнең өчен аның исеме дә җырга әверелде, республикабыз чикләрен үтеп, бөтен дөньяга яңгырады.* Хезмәт даны

**2.** *с. мәгъ. лингв.* Тавыш катнашында әйтелә торган авазлар (аваз тур.), киресе: саңгырау. *Аерым алынмалар, сүзлекләрдә башкача теркәлгән булуларына карамастан, я алгы, я арткы рәт сузыклары белән генә языла, сүз ахырындагы яңгырау тартыкларны саңгырау парлары белән алыштыру да очрый.* Р.Мөхиярова

**Яңгырый башлау** Яңгырарга тотыну. *Кичке тынлыкта әлеге көйле аваз тагын да дәртләнебрәк, тагын да күңелләргә үтебрәк яңгырый башлады.* Г.Бәширов. *Шулчак саф татарча җырлаган бер кыз бала тавышы яңгырый башлады.* М.Хәсәнов

**Яңгырап кую** Кинәт кенә яңгырау. *Сакчылар чираттагы тоткынны алып киттеләр, яңадан пистолет тавышы тонык кына яңгырап куя.* Г.Әпсәләмов. *Чинау, курку тавышлары яңгырап куя.* З.Хәким

**Яңгырап тору** Гел, әледән-әле яңгырау; хәзерге вакытта, әле яңгырау. *Рөстәм Яхин әсәрләре күңелдә гел яңгырап торалар.* Л.Шагыйрьҗан. *Ура тавышы якындагы тауларга бәрелеп, кайтаваз булып бик озак яңгырап торды.* Р.Сәгъди

**ЯҢГЫРАУЛЫ** *с.* 1) Яңгырап ишетелә торган. *Ул баскычтан беренче булып йөгереп төшеп китте, һәм артыннан шартлап ябылган ишекнең яңгыраулы кайтавазы бөтен подъезд буйлап чарлакка кадәр таралды.* Ә.Мушинский. *– Урыннардан кузгалмаска! – дигән яңгыраулы боерык тавышын ишеткәч, талаучылар тизрәк табан ялтырату җаен эзләделәр.* Ш.Шәйдуллин

2) Яңгырап тора торган, авазны, яңгыратып, кире кайтара торган. *Яңгыраулы гөмбәзләр*

**ЯҢГЫРАШ** *и.* 1) Яңгырау рәвеше. *Исеменең яңгырашы да матур*

2) *к.* **кайтаваз**. *Ферма артындагы таулардан көчле яңгыраш әйләнеп кайтты.* Г.Әпсәләмов

**ЯҢГЫРАШЛЫ** *с.* Билгеле яңгырашы булган, билгеле рәвештә яңгырый торган. *Руслан авызыннан үзем өчен бик таныш, сирәк яңгырашлы исемне ишеткәч, гаҗәпләнеп, башымны күтәрдем.* А.Әхмәтгалиева. *Ул үзен, хәтта кайда икәнлеген дә онытып, гаҗәеп матур яңгырашлы музыка дөньясына килеп эләккәндәй хис итте.* Г.Галиева

**ЯҢГЫР БАШМАГЫ** *и. бот.* Шампиньончалар гаиләсеннән булган, итләч йомшагы өлгергәннән соң каракучкыл тузанга әйләнә торган шарсыман гөмбә; *русчасы:* **дождевик**

**ЯҢГЫ́Р БОТКАСЫ** *и. этн.* Яңгыр теләү йөзеннән, күмәкләшеп, казан асып ботка пешерү йоласы. *Йорт саен берәр савыт сөт, күкәй һәм берәр уч ярма җыеп, яңгыр боткасы пешерделәр.* М.Галәү. *Ул арада, чишмә буенда яңгыр боткасы пешерәләр, дигән хәбәр таралды.* Г.Бәширов

**ЯҢГЫРЛА́У** *ф. з.-сыз* Яңгыр сибәләү яки яңгырлар еш булу. *Көзен яңгырлый*

**Яңгырлый башлау** Яңгырларга тотыну. *Иртән яңгырлый башлады*

**Яңгырлап тору** Хәзерге вакытта яңгырлау. *Бу көннәрдә яңгырлап тора*

**ЯҢГЫРЛЫ** *с.* 1) Яңгыр явып торган, явым-төшемле. *Кадыйр үзе болай яңгырлы елда да туган иде.* А.Алиш. *Яңгырлы көз*

2) Яңгыр китерә, яңгыр яудыра торган. *Торналар да моны сизә: лычма яңгырлы болытлар килеп җиткәнче күченеп калырга тырыша.* З.Мурсиев

**ЯҢГЫРЛЫК** *и. сөйл.* Су үткәрми торган материядән тегелгән, яңгырда кия торган махсус кием; яңгыр плащы. *Төштә яңгырлык, ягъни плащ күрсәң, дәүләт, дәрәҗә, дәрәҗәле кием булыр, ди Мөхетдин бине Гарәби.* Ф.Яхин. *Шириязданның өстендә җылы тотарлык хәле калмаган кечерәк бер яңгырлык була.* Р.Батулла

**ЯҢГЫРСЫЗ** *с.* **1.** Яңгыр булмаган, явымсыз, корылыклы. *Шәлпек ирennәр яңгырсыз елда эсселектән корып киткән яфрак диярсең.* С.Поварисов. *Җилсез, яңгырсыз кызу көннәрне таллар елый.* Х.Ширмән

**2.** *рәв. мәгъ.* Явымсыз, яңгыр яумыйча гына. *Шулай итеп, июнь яңгырсыз үтте.* Ф.Садриев

**ЯҢГЫРСЫЗЛЫК** *и.* Яңгыр, явымтөшем булмау хәле, корылык. *Ләкин соңгы бер-ике атна эчендә һәммәсенең күңелләрен бер әйбер борчый: яңгырсызлык.* Ш.Камал. *Ике тарафның елга кырые – яшел агачлар, бай яфраклы, яңгырсызлык сәбәпле көйгән басулар күренми.* Г.Баруди

**ЯҢГЫ́Р ТЕЛӘНЧЕСЕ** *и. зоол. к.* **шәүлегән**

**ЯҢГЫ́Р ЧЫПЧЫГЫ** *и. зоол.* Шөлди кошлар семьялыгыннан туры кыска томшыклы, озынча кыска канатлы, муенында аклы буй булган кош; *русчасы:* **зуёк**

**ЯП-** *кис.* [йа] авазына башланган кайбер сыйфатларның артыклык дәрәҗәсен ясый торган алкисәкчә. *Туңып беткән агачның яп-ялангач бер ботагында Төшәр-төшмәс торадыр соңга калган бер генә яфрак, Төшәм дип калтырый, җил сызгырып киткән саен чак-чак.* Г.Тукай. *Яп-якын шәһәрләрнең дә тик исемнәрен генә ишеткән иде.* Г.Ибраһимов. *Яп-яңа юл бик матур, Тип-тигез булып ятыр ---.* Ш.Галиев. *Мәгълүм билгесезлек томанында Яп-ят тойгыларга күмелеп Яшәү җиңел түгел, җан-җанашым ---.* Л.Шагыйрьҗан

**ЯПА-** *кис.* [йа] авазына башланган кайбер сыйфатларда «бөтенләй», «тулысынча» мәгънәсен белдергән алкисәкчә. *Мин бәхет эзләп киткәч, ул, мескенем, япа-ятим калган икән.* А.Гадел. *Галәмдә түгел, торган, яшәгән җиреңдә япа-ялгызың каласыңмы?* А.Хәсәнов. *Тик урынымны япа-яланнан сайлама.* А.Хәлим

**ЯПАН** *и. диал.* **1.** 1) Киң дала яки урман-кырсыз, авыл-кешесез җир. *Гүя япанда үлеп калган бөек бер пәһлеванның корышкан кабырга сөякләренә бакалар оя ясыйлар!..* Н.Думави. *Бай кызы, карынындагы ике айлык баласы белән, япанда ялгыз калган кебек хәлгә төшә.* Г.Ибраһимов

2) Кыр, ялан; ачык, сыену урыны булмаган җир. *Немец кола япанда атакага чыкса, салкыннан катып тәгәрәгәнче, аның вакыты бернichә сәгать кенә...* З.Зәйнуллин. *Сакманов аның япанда ялгыз үскән агач икәнен белә иде.* Т.Галиуллин

**2.** *с. мәгъ.* Ачык, буш, ялангач. *Шул караңгы төндә япан кырда берүзе калган әти.* В.Нуруллин. *Дөрес, якындагы япан дала сулышы монда беркадәр сизелерлек, әлбәттә.* Л.Хәмидуллин

**ЯПАНЧА** *и. иск.* Киң плащ формасындагы җиңсез борынгы өске кием; *русчасы:* **епанча**. *Япанга чыксаң, япанча ал.* Мәкаль. *Карета алдыннан тантаналы кыяфәт белән яшел япанча кигән, атка атланган ике ир бара.* Җ.Тәрҗеманов

**ЯПАНЧЫ** *и. иск.* Япанда яшәүче, япан кешесе. *Еллар авыр килде япанчыларга, Ком бураннары аша ничек чыгарга?* Җыр

**ЯПКЫН** *и. сөйл.* Ирektән мәхрүм итү урыны; сак астында булу. *Нәгыймә дә япкыннан кайтты, янә эшкә урнашты.* Б.Камалов. *Әмма казыйлар аны 2,5 елга гомуми режимдагы япкынга озатырга һәм 800 мең тәңкә түләргә хөкем итә.* Мәдәни җомга

**ЯПКЫЧ** *и.* 1) Нәрсәнең дә булса каплавычы, капкачы. *Кәстрүл япкычы* // Нәрсәнең дә булса юлын яба, томалый торган әйбер. *Морҗа япкычы*

2) *тех.* Нинди дә булса механизмда пар, газ, сыеклык һ.б.ш. үтә торган каналны каплау өчен махсус клапан

**ЯПМА** *и.* **1.** 1) Нәрсәне дә булса ябу, каплау өчен махсус тукыма кисәге. *Менә олы палатканың ишек япмасы күтәрелә.* А.Гыйләҗев. *Әле монда икмәк җәю өчен брезент япмалар җитми, әле тегендә ашлык киптерү машинасы тыгылып туктый.* В.Имамов // Диван, караваṭ һ.б.ш. җиһазлар яки урын-җир өстенә ябу өчен, тукымадан эшләнгән җиңел җәймә. *Түр яктагы мендәр-ястыклар өстенә бик матур чиккән япма капланган.* Г.Бәширов. *Йокы бүлмәсенә әтием, өй бүләге дип, агач төсендәге караваṭ белән шундый ук кием шкафы китертте, ачык яшел*

*төстәге япмалар, үтәкүренмәле яшел пәрдәләр тегеп куйгач, бу бүлмә дә хан сараена охшап калды.* А.Әхмәтгалиева

2) Кәләшнең челтәрдән тегелгән баш киеме; фата, бөркәнчек. *Ә япмасы аша аларның яшь йөрәкләре кушылганны тантана итүчеләрне карап баручы Гөлсия үзен шаһиндә итеп тойды.* А.Нәҗми

3) Чәчтарашханәдә хезмәт күрсәткәндә клиентның киемен буямас өчен өстенә ябыла торган җаймә; пеньюар. *Настя аның иңнәрен япма белән төрде дә эшкә кереште. – Нинди причёска?* М.Кәбиров

4) Ат өстенә ябу өчен махсус эшләнгән җаймә. *Ул кучердан иске бер ат япмасы сорап алып, шуннан капчык тектe дә, салам тутырып, үзенә түшәк ясады.* М.Галәү. *Аларның атларына чигүле япмалар ябылган иде.* Н.Фәттах

5) Кояштан, җил-яңгырдан саклау өчен, баганалар яки башка төр терәкләр өстенә каплап эшләнгән өслек, түбә. *Мин, нәчәлникләр утыра торган япма астына кереп, көрәшнең соңгы өлешен карарга керештем.* Т.Нәҗмиев

6) Кардан, салкыннан саклау өчен махсус корылма. *Фонтаннарны агач япмалар белән каплау*

7) *күч.* Нәрсәне дә булса каплап, төреп алган катлам. *Танк колоннасы, иртәнге томан япмасы астында, чигенү аркасында хәлсезләндерелгән дошман оборонасы аша үтә башлады.* Ә.Әминев. *Ишегалдындагы бердәнбер алмагач яфраклары, калын тузан япмасыннан арынып, ямь-яшел төскә керде.* Ә.Хәсәнов

**2.** *с. мәгъ.* Ябу, каплау өчен хезмәт итә торган. *Артык кылычны биленә такты, ишек яры эленеп торган садакны, җәяне алды, япма чүпрәкне ачып, тышка күз салды.* М.Хәбибуллин. *Яңа ел чыршылары ашлама буларак кулланыла алмый, әмма алар – үсемлекләрне каплау өчен бик әйбәт япма материал.* Әлмәт таңнары

**ЯПОН** *и.* Япониядә яшәүче төп халык атамасы һәм шул халыкның аерым бер вәкиле. *Кызганычка каршы, монда әллә ниткән саксон фарфоры, япон тәлинкәләре.* А.Тимергалин. *Хәсәновлар нәселенә нигез салучы Хәсән бабам Әбү агасы белән күп дөньяларны кичә, исәп-хисап эшенә төшенә, күп телләрдә сөйләшә: япон, фарсы, һинд телләрен белә.* А.Хәсәнов

**ЯПО́НИЯЛЕ** *и.* Япониядә туып үскән һәм шунда яши торган кеше. *Җир йөзендәге иң өлкән ир-атка бүген 112 яшь. Япониялe Сакари Момои бүген үзенә 112 яшь тулуны билгеләп үтә.* Әлмәт таңнары

**ЯПО́НЧА** *рәв.* **1.** 1) Япон телендә. *Касыйм хаҗи, японча да, русча, татарча да тутырып, өч нөсхәдә чакыру язып салган.* В.Имамов. *Японнар белән японча, испаннар белән испанча да якаларыннан тотып бәхәсләшә.* А.Хәсәнов

2) Японнар кебек. *Икесе дә чибәр, икесе дә японча киенгән һәм бик мул итеп иннек-кершән ягынган япон кызлары безнең вәкилләргә чәчәк бәйләмнәре --- бүләк иттеләр.* А.Хәсәнова. *Хәзер исә бәйрәмдә дә, атна уртасында да японча тукланып алабыз.* Әлмәт таңнары

**2.** *с. мәгъ.* 1) Япон телендә булган. *Бу урынның кытайча һәм японча атамалары да «култык – бухта» дигәнне аңлата.* Ф.Бәйрәмова

2) Японнарга караган, японнарга хас булганча, японнарда гына булган. *Малайлар бигрәк тә Омоссу белән Хейтоконың японча сугышуларына мөкиббән киттеләр.* Р.Миңнуллин. *Японча санау системасында саннарның абстракт (ягъни сан буларак аерым гына куллану) мәгънәләре юк.* Р.Һади

**3.** *и. мәгъ.* Япон теле. *М.Талвест пьесалары чит илләрдә дә куела, аларның берсе японча да тәрҗемә ителгән икән.* Т.Әйди

**ЯПСАРУ** *ф. диал.* 1) Бер япманы икенчесенең кырыен ябарлык итеп салу, кырыен каплау

2) Кемгә яки нәрсәгә дә булса сылтау. *Хуҗа Насретдин урынына мәзәк итеп сөйлиләр, төрле кызык хәлне аңа япсарырга яраталар.* Н.Фәттах. *Әйдәгез, бу кимчелекләрне кырыс заманга япсарыйк.* А.Тимергалин

3) Яклау, гаебен күрсәтмәскә тырышу. *Юк, син аны азрак япсарып маташасың.* Ш.Камал

**ЯПЬ** I *и.* 1) Агачның икегә яки берничәгә аерылган, ботакланган кәүсәсе яки ботагы; аерча. *Үзе бер, ябе дүрт, Һәр япьтә бишәр ботак.* Табышмак. *Бишалты япьне пәкем белән һәйбәтләп кисеп алгач, күлмәк эченә яшердем дә очып кына җиргә төштем, өйгә кереп тормыйча, урамга элдерттем...* К.Миңлебаев. *Имән таягының япьләре белән шалаш алдындагы тапталган төшләрне тырмаштырды Габдулла ---.* М.Хуҗин

2) Үремдәге, баудагы бер учма. *--- бу – аталарының яшь чагында тоып йөргән кыска саплы, күн чуклы, өч япьле, һәр ябенең очына көмеш пластинка бөкләп кидерелгән бик шәп камчысы иде.* Ә.Еники. *Расчалканың бер ябе юкка чыкты.* Ш.Рәкыйпов

3) Сәнәк, чәнечке, ачкыч кебек нәрсәләрнең аерчасы яки теше. *Сынды шулчак аткычның Ике ябе, шарт итеп.* Х.Халиков. *Фәһимә тиз-тиз генә сәнәк япьләренә елан кабыгын урады да «күчтәнәч»не арт капкадан гына Рокыялар сараена кертеп ташлады.* Н.Гыйматдинова. *Әгәр чәнечкене шәм ялкынына параллель итеп вертикаль урнаштырсак (рәс. 376), чәнечкенең япьләре экранга төшкән күләгәдә ачык күренә.* Физикадан мәсьәләләр җыентыгы

4) Аерча сыман эшләнгән коралларның бер тәпие. *Каш йолку эскәгенең япьләре яссы һәм очлы булганын сайлагыз.* Сөембикә

5) Телем-телем булып торган нәрсәләрнең бер теле. *Чатырның иң очына беркетелгән биек колгада – тугыз ябен җилдә уйнаклатып барган ап-ак әләм.* В.Имамов

6) Ачыла-ябыла, җыела торган коралларның аерча хасил иткән бер бүлеме. *Солтан пәкенең япьләрен ачып-ябып карады.* Р.Хафизова. *Степлер ябе*

7) *сөйл.* Төп чыганактан, нигездән аерылып чыккан тармак. *Борынгы бабаларына нисбәт ителгән «әт-Талкышый» атамасы бу нәселнең төбе, яисә бер ябе Чистай өязендәге Татар Талкышы белән бәйләнүен күрсәтә.* Р.Әмирхан. *--- ата җенестән булган ташбакаларның койрыгы юанрак һәм кыскарак була, 1 яшьтән соң аларның тырнаклары озын булып үсә башлый һәм, акрынлап, өч озын япькә әверелә.* Ялкын

**ЯПЬ** II *и. иск.* Рәт, юнь. *Ибе килсә, ябе килми.* Мәкаль

**ЯПЬ-** *кис.* [йә] авазына башланган кайбер сыйфатларның артыклык дәрәҗәсен ясый торган алкисәкчә. *Башта әле мин сезгә шуны әйтергә тиеш: ул чагында әле мин дә сезнең шикелле япьяшь егет идем.* А.Шамов. *Кайчан гына алар ире Сәйяр белән япь-яшь студентлар иде.* А.Гыймадиев

**ЯПЬЛЕ** *с.* Ябе булган; япьләнеп торган, аерчалы. *Тик тормышның җитмеш җиде япьле юлында буталып, вакланып, үз кыйбласын таба алмыйча калган.* М.Хәсәнов. *Ничә тапкырлар әйткәнем бар сиңа, энем: шул язган киягазеңнең өске өлешенә япьле сәнәк төшереп куй, диеп.* З.Зәйнуллин

**ЯПЬЛЕКӘ** *и. сөйл.* Япьләре булган нәрсә. *Ирләре ахырдан, әдәп саклап кына чыктылар, берсе ярым хәрби формадан, уң кулы беләзектән юк, кул сөяге икегә аерылып япьлекә ясалган иде.* М.Мәһдиев

**ЯПЬЛЕКӘЛЕ** *с.* Япьлекәсе булган. *Бу сорауны япьлекәле кул бирде.* М.Мәһдиев

**ЯПЬТӘШ** I с. *диал.* Сәләтле, җитез, өлгер, оста. *Сакау күп сөйләр, дигәндәй, татарчасы бик шома булмаса да, сүзгә япьтәш адәм булып чыкты ул.* В.Нуруллин. *Эшкә япьтәш кенә күренә болай.* А.Гыйләҗев. *Ул табигате белән япьтәш кебек иде.* Х.Камалов

**ЯПЬТӘШ** II *и. диал.* Аркадаш, ярдәмче; партнёр, кулдаш. *Аннары ул белә иде: сугышта иптәш кирәк, дөресрәге, япьтәш кирәк.* Г.Гыйльманов

**ЯПЬТӘШЛЕК** *и. диал.* Япьтәш (I) булу үзлеге. --- *Габделәхәтнең дә тырышлыгы, япьтәшлеге берлә, укыта алса, зур кеше булачагын исәпләп, укытмый надан калдырып әллә нинди зур дәрәҗәләрдән буш калдырасын уйлап, укытырга теләсә дә, үзенең байлыгы юкка, барасы кешесе кем булса да дошманының ике баласын тәрбия кыла алмаганга, Габделәхәтне асраулыкка бирүне кистереп куйган иде.* Г.Исхакый

**ЯП-ЯЛАНАЯК** *ы.* Берәр сүгенү сүзе урынына кулланыла. – *Яп-яланаяк, – дип сүгенде ул, гадәтенчә яратып.* А.Гыйләҗев. *Анасы, анасы, дим, яп-яланаяк, яңа мендәр сал урындыкка!* Н.Әхмәдиев. *Нишлисең син, яп... яланаяк!* Л.Лерон

**ЯР** I *и.* 1) Сулыкка орынып торган коры җир чите. *Үзендә ниндидер арганлык сизеп, егет сөзәк ярга утырды.* А.Гыйләҗев. *Көч-хәл белән ярга йөзеп чыгып, ярты көн хәл җыеп яттым.* А.Тимергалин // Су буеның текә урыны

2) Яңгыр, су белән юылып, ашалып, ишелеп ясалган ерым, чокыр

**ЯР** II *и. фар.* Яраткан, сөйгән кеше (кыз яки егет). *Кемнәр әйтер, гомерлеккә Булчы минем ярым, дип.* Ф.Яруллин. *Син генә ул моңлы сазым, син генә ул якты хыялым. Син генә ул минем ярым. Син генә ул минем парым, Син генә, син генә...* Р.Вәлиев

**ЯР** III *и. к.* **җар**. --- *Туктамыштай олы хан Урдасына яр салды.* Дастан. *«Янам», – диеп яр салу да Мондый чакта килешмәс* ---. Р.Идиятуллин

**ЯРА** *и.* 1) Тән тукымаларында, эчке органнарда берәр корал белән җәрәхәтләнгән, пешүдән яисә ялкынсынудан зарарланган урын; җәрәхәт. *Болай яту аңа кыен, әмма чалкан ятарга һич мөмкин түгел – аркасындагы яралары бик каты сызлый иде.* В.Нуруллин. *Сораган кешегә, ашказаны ярасы белән ятам, диярсез.* М.Хафизов

2) *күч.* Рухи газап, борчу. *Ата-аналар күңел яраларын бер чакта да күрсәтмиләр.* А.Гыйләҗев

3) *күч.* Сугыш, янгын, гарасат һ.б.ш. вакыйгалар китергән зур фаҗига; авырлык. *Шәхес культының илгә, халыкка китергән авыр яралары турында тыңлаганда, Гөлшәһидәнең йөрәге аз әрнемәде.* Г.Әпсәләмов. *Кырык бер ел үтте, әле һаман беткәне юк шул сугыш китергән яраларның.* В.Нуруллин

◊ **Ярага тоз салу** Эчке газапны, борчуны кузгату, тагын да борчылырга мәҗбүр итү. – *Син, энекәш, үткәннәрне искә төшереп ярага тоз салма әле, – диде ул аңа.* Г. Әпсәләмов. – *Син, Рәхимҗан абый, – диде ул, ярсуын чак-чак тыеп, – ярага тоз салып йөрмә.* Ф.Яруллин. **Ярага тоз сибү** *к.* **ярага тоз салу**. *Ул гына җитмәсә тагын, киселгән ярага тоз сипкән кебек, кочегар турында да берсеннән-берсе караңгырак сүзләр таралып китте.* Г.Ибраһимов. *Тагын килер кебек иде ул, тагын ярага тоз сибәр кебек иде.* Н.Гыйматдинова. **Яраны кузгату** *к.* **ярага тоз салу**. *Шул сәбәптән, бүген дә аны шул кыяфәттә күрү җыйналган халыкның күңелендәге әллә кайчангы һәм әллә нинди яраларны кузгатты; ул яраларны ниндидер көч үткен тырнаклар белән тырнап әрнетте.* М.Галәү. *Сүз үрчетә, бәхәсләшә, яраларны кузгата торган чакмыни.* И.Нәбиуллина

**Я́РАББИ** *ы. гар.* 1) Гаҗәпләнү, соклану, нәфрәтләнү һ.б.ш. хисләрне белдерә. *Ярабби, бирсә дә бирә икән табигать адәм баласына тазалык-саулыкны!* В.Нуруллин. *Ярабби, дөньяга никадәр матур хатын-кызлар яраткансың, ә мин колыңа – больница түшәге.* Г.Әпсәләмов

2) Көчле теләк, үтенүне белдерә. *Тормышның асылы үзгәрмәсен, илдәге гадәтләр шул килеш дәвам итсен, халык җитәкчеләрен зурласын, ярабби!* А.Гыйләҗев. – *Шатлык өстенә шатлык булып, ярабби, Нургалиең дә кайтып җитсә ие, – дип, ахирәте өчен шатлануын белдерде Саҗидә.* Г.Галиева

**Я́РАББЫМ** *ы. к.* **ярабби**. *[Җәмилә (түшәмнәргә, диварларга карап):] Яраббым, Ходаем! Үзең сакла! Мондый урыннарны дошманга да насыйп итмә.* Г.Камал. *Яраббым, бу нинди эш булды соң?* Т.Гыйззәт

**ЯРА́ ГӨЛЕ** *и. бот. к.* **алоэ**

**ЯРАК** *и.* 1) Кирәкле нәрсә. *Шаһмөхәммәт байларның өендә дә туй яраклары, мәҗлес кирәкләре хәзерләнгән иде.* Г.Исхакый

2) Нәрсәдер кирәк булу очрагы; ихтыяҗ. *Якты көнем, күлмәк булып тегел – Кирәк чагың тормыш ярагына!* Ф.Яхин

**ЯРАКЛАШТЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **яраклашу** (1 мәгъ.). *Үзеңә кулай шартлар эзләп йөргәнче, бәлки, күңелеңне үзгәртеп корырга, урындагы шартларга яраклаштырырга кирәктер?* Р.Вәлиев. *Яңадан тарихка күз салсак, мең еллар буе һәр төбәктә «халык селекциясе» яшәгән: кешеләр, климатка яраклаштырып, үз сортларын чыгарганнар.* Ватаным Татарстан

2) Берәр нинди таләпләргә туры килә торган итү, берәр нәрсәгә яраклы итү; туры китерү, ипләштерү. --- *блиндажларны ныгыттылар, амбразуралары көнчыгышка каратып ясалган дошман дзотларын үзгәртеп, көнбатышка таба атыр өчен яраклаштырдылар.* Г.Әпсәләмов. *Кышкы пальтога яраклаштырып, кубанка да алынды.* Р.Гаязетдин

**Яраклаштыра башлау** Яраклаштырырга керешү. *Мадам Малкин Һаррины егет каршындагы икенче урындыкка бастырды һәм, башыннан озын мантияне кидереп, дөрес үлчәмгә яраклаштыра башлады.* Җ.Роулинг

**Яраклаштыра төшү** Бераз яраклаштыру; тагын да яраклаштыру. --- *яшьләр безнең хикәянең төсен һәм кыяфәтен яңарта, заманга яраклаштыра төшетеләр.* Ф.Миңнуллин

**Яраклаштырып бетерү** Тулысынча яраклаштыру. – *Кибет бинасын сату эшләре өчен санитар нормаларга яраклаштырып бетергәнче, бер ай вакыт узды, – дип искә төшерә Алсу апа беренче вакытларын.* Шәһри Казан

**Яраклаштырып тору** Әледән-әле яки даими яраклаштыру. --- *тормыш агышына нисбәтән әдәбият фәне дә үсеш-үзгәреш кичерә: шәрех-аңлатмаларын, төшенчәләрен барлап, чор ихтыяҗлары белән яраклаштырып тора.* Х.Миңнегулов

**ЯРАКЛАШУ** *ф.* 1) Билгеле бер климатка, урынга җайлашу, ияләшү (үсемлек, хайван, кешеләр тур.). *Сабыр кеше генә Табигатьне тоя ала, Табигать*

*ритмына яраклашып яши ала.* Г.Гыйльманов. *Коры климатка яраклашып, сөтлегән шушы чәнечкеләрендә дым туплый.* Материклар һәм океаннар географиясе

2) Нәрсәне булса да өйрәнеп, тәҗрибә туплау, теге яки бу нәрсәдән файдалана белү, уңышлы эшләү. *Директорның зирәк җитәкчелеге белән предприятие яңа икътисади шартларга гаять тиз һәм уңышлы яраклашты.* Г.Мөхәммәтшин

3) Ияләшү, күнегү, гадәтләнү. *Тәзкирәне әйтәм, улым булышыр дип юкка өметләнә: ул малайның куллары бер дә сәнәк тотарга яраклашмаган.* И.Хәйруллин

4) Яңа шартларга яки кешеләргә җайлаша алу; шуларга карап үзгәрү; үзләшү. *Оятсыз да икән, тукмакборын. Җилнең кайсы якка таба исә башлавын нинди тиз сизеп, нинди җәһәт яраклашырга тырышты.* Г.Әпсәләмов

5) Ярарга тырышу, җаена тору. *Иренә, кайнанасы, кайнатасына, шартларга яраклаша белгән хатын – батыр хатын.* Р.Батулла

**Яраклаша бару** Акрынлап яраклашу. *Ни әйтсәләр шуңа күнеп, Яраклаша барасың – Үз-үзеңнән торган саен Ераклаша барасың...* Ш.Галиев. *Акрынлап, торгынлык елларында урнашкан шартларга берәүләребез – күнегә, икенчеләребез яраклаша бардык.* Ә.Закирҗанов

**Яраклаша башлау** Яраклашырга тотыну. --- *аксөякләр җил кайсы тарафка иссә, шуның уңаена бөгелә һәм яраклаша башлый.* В.Имамов. *Пестицидлар һәм кайбер башка химик кушылмалар безне агулап кына калмыйлар (астма, аллергия, рак һ.б. авырулар), ә бәлки гормоннарга яраклаша башлыйлар икән.* Татарстан яшьләре

**Яраклаша төшү** Бераз яраклашу; тагын да яраклашу. *XX йөз башында ирләр камзулы Европаның яңа кием төре – жилетка яраклаша төшкән.* Сөембикә

**Яраклашып алу** Тиз яраклашу. --- *үзен күрсәтергә сәләтле булганнар тиз яраклашып алды бу хәлгә.* Кызыл таң

**Яраклашып бару** Акрынлап яраклашу. *Бүген --- Ватан сугышы, аның каһарманнары турындагы мәгълүмат та елдан-ел заманга яраклашып бара.* А.Әхмәтгалиева

**Яраклашып бетү** Тулысынча яраклашу; барысы да яраклашу. *Октябрь революциясенә чаклы бу мәсьәлә гамәли яктан өзелеп, иске гарәплектән котылып, татар теле фонетикасына яраклашып бетәр дәрәҗәгә килеп җиткән иде инде.* Г.Алпаров. *Рушания да аның холкына яраклашып беткән: каршы сөйләшми, йомшак кына итеп «ярый» дип кенә тора.* З.Кадыйрова

**Яраклашып җитү** Кирәк кадәр яраклашу. *Әмма шушы яңа дәүләт көнесәгате белән үзгәреп торучы дөньяга яраклашып җитә алмаган икән.* Татарстан яшьләре

**Яраклашып китү** Нindидер сәбәптән, вакыттан соң яраклашу; әкренләп яраклашу. *Килмешәкләр әүвәл кытайларга яраклашып китә алмый тәмам иза чикте.* В.Имамов. *Алар кытайларның сәер гореф-гадәтләренә, көнкүрешенә яраклашып китә алмыйча да озак интегәләр.* Китапларда – тарих сурәте

**Яраклашып тору** Даими яки туктаусыз яраклашу. --- *тарихи-публицистик чигенешләр әсәрнең төп аһәңе белән яраклашып торалар.* Х.Миңнегулов

**ЯРАКЛЫ** *с.* 1) Берәр эшкә ярый торган; файдаланырлык. *Мәгълүм булганча, күкне күзәтү өчен яраклы беренче телескопларны Галилей белән Кеплер ясаган.* А.Тимергалин. *«Падишаһ» аңа кафтанга яраклы ал материя бүләк итә, гаскәр җыярга фәрман биреп җибәрә.* В.Имамов

2) Нинди дә булса таләпләргә җавап биргән, туры килгән, кулай. *Шунда берочтан фронтка барырга яраклы ирләрнең исемлеген дә терки барырбыз.* В.Нуруллин

3) Чак, таман; уңай; килешле. *Миңа яраклырак пальтоларның бәяләрен дә сораштырып карый, чалбар, бүрекләргә дә күзе төшә иде.* В.Нуруллин. *Өсләреннән «OS» тамгалы киемнәрне салып ташлаганнар да складтан үзләренә яраклы киемнәр табып алып киргәннәр.* Ф.Хуҗин

**ЯРАКСЫЗ** *с.* **1.** 1) Файдаланырга ярамый торган, файдаланып булмый торган; файдасыз. *Суырлар ояларыннан өннәрен сөрергә, ни дә булса чәчәргә яраксыз уңдырышсыз, хәтта көтү йөртергә дә уңайсыз, ташландык җирләргә, таулы-ташлы яссы тау битләренә казыйлар.* А.Хәсәнов

2) Бозык, бракли, түбән сыйфатлы. *Берәүләре таланып, кесәләрен кистертеп кайткан, икенчеләренә яраксыз, бозык товар тоттырып җибәргәннәр, өченчеләре, Сафа белән Саҗидә шикелле, полиция мәркәзенә эләккән иде.* М.Галәү

3) Билгеле таләпләргә җавап бирми торган; начар. *Ул бу сыйфаты – үзенең яраксыз ягы икәнен үзе дә сизә.* Г.Ибраһимов. *Яраксыз организмнар сызып ташланган.* А.Тимергалин

**2.** *и. мәгъ.* Билгеле таләпләргә туры килмәгән әйбер яисә зат. *Нишләп яхшы, тугры кешеләрем күбрәк үлә, бернәрсәгә яраксызлары исән, яшиләр, минем тирәдә кыймылдыйлар?* З.Хәким. *Күпмедер вакыт үткәч, складтагы киемнәрне барлап, яраксызларын юк итәргә дип аерып утырган интендант бер куртканың түш кесәсеннән конверт табып алды.* З.Мурсиев

**ЯРАКСЫЗГА** *рәв.* Бушка, тик, файдаланылмыйча. *Мактап, зурлап, сагынып язасыз да – Киштәләрдә ята мәдхияләр, Тузан җыеп, аунап, яраксызга.* З.Хәким

◊ **Яраксызга калу** Билгеле таләпләргә җавап бирми башлау. *Әсәрләр, әһәмиятен җуеп, яраксызга калганнан түгел.* М.Гайнетдин. **Яраксызга чыгару** Яраксыз, файдасыз, кирәксез дип табу. **Яраксызга чыгу** *к.* **яраксызга калу**. *Әгәр бу проектыңны яраксызга чыгарып, заданиене икенче кешегә тапшырсалар, абруеңа бик каты сугачак.* М.Маликова

**ЯРАКСЫЗЛАНУ** *ф.* Яраксыз хәлгә килү, яраксызга әйләнү, эшкә ярамау. *Әнә бит ургып агып торган куәтле елга, торгын сулы күл кебек, акрынлап сөрси, өсте яшелләнә, суы эчәргә һәм балыклар яшәргә яраксызлана, акрынлап һәлакәткә бара.* С.Сабиров

**ЯРАКСЫЗЛЫК** *и.* Яраксыз булу сыйфаты. *Боларда бәя, мөнәсәбәтләрдәге элеккеге берьяклы үлчәмнәрнең яраксызлыгы бик дөрес күрсәтелә.* Ф.Хатипов

**ЯРАЛАНУ** *ф. төш. юн. к.* **яралау**. *Җаек аръягыннан килгән дошман гаскәре Алтынчәчнең туган җирен таптый, Алтынчәч, кулы яраланып, тау куышына чигенә һәм шунда кача.* М.Мәһдиев. *Аның кулы, аркасы һәм яңагы яралана.* В.Имамов

**Яраланып алу** Җиңелчә яралану; тиз арада ярлану. *Бу тырыш егет яраланып алырга өлгергән, Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнгән ---.* Безнең гәҗит

**Яраланып бетү** Берничә урыннан яралану; күп тапкырлар яралану. *Корымланып беткән ябык йөзе, Яраланып беткән куллары.* М.Җәлил. *Зөлмәт җиз башаклы сөңгесен Марисның*

*--- күп яуларда яраланып беткән киң, таза күкрәгенә тондырды.* Н.Фәттах

**Яраланып китү** Кинәт яралану. *Тик яраланып китмәсен дә үлмәсен, җиңү көнен Германиядә үткәрергә насыйп булсын!* С.Поварисов

**ЯРАЛА́У** *ф.* 1) Тән тукымаларын яки эчке органнарны берәр очлы, үткен яки авыр нәрсә белән зарарлау, утлы корал белән җәрәхәтләү. *– Яралап китереп ташламадылар микән? – дип шикләнүен белдерде Рамазанов.* Ш.Шәйдуллин. *Кырда кулын яралап, эшкә чыга алмаган Әптерәй --- аның янына керде.* Г.Сабитов

2) Нәрсәгәдер зур зыян китерү. *Агачларны яралау. Җирне яралау*

3) *күч.* Кемгә дә булса кайгы китерү, газаплау, борчу; күңелен әрнетү. *Ләкин аптырыйм: ник сез боларны сөйләп, үз йөрәгегезне яралыйсыз?..* Г.Ибраһимов. *Яман тел пычактан хәтәр яралый.* А.Гыйләҗев

**Яралап алу** Тиз арада яралау. *Күркәч батыр, онытылып, ачу белән кизәнгән иде, Надирның кырыйга кагылып калуы булды, кылыч аңышмый калган Сатыкның аркасын яралап алды.* Р.Сәгъди. *[Чәчәкнең энәләре] Әкрен генә кагылуга, кызның нәфис бармакларын яралап алдылар.* А.Хәйретдинова

**Яралап бетерү** Бик нык яралау. *Тайның кырык бер кат киемен өзгәләп, үзенең итләрен талап, яралап бетергән булалар.* Әкият. *Снарядлар, бомбалар актарып, яралап бетергән хәсрәтле җир өстенә әкрен-әкрен генә караңгылык пәрдәсе сарыла иде.* Г.Әпсәләмов

**Яралап кую** Кинәт, ялгыш яралау. *Юатырга теләп, Кояш карый Күксел болытларны аралап. Яшь аралаш моңсу елмаюы Йөрәгемне куя яралап.* И.Иксанова

**Яралап ташлау** Кинәт, уйламастан яралау. *Кулымны чыгарып көбәкне ычкындырыйм дигәндә генә, бар отделение күз алдында, адашкан ядрә мине яралап ташлады.* А.Хәлим

**Яралап тору** Әледән-әле яралау. *Чөнки җанын кимсетеп, күңелен яралап торган бер нәрсә бар: утны-суны кичкән батыр солдат бүген ике маңкуш малай алдында тез чүгеп, аларга хәләл акчасын биреп бара ---.* Р.Габделхакова

**Яралый башлау** Яраларга керешү. *Аннары ул аның тәнен кыра, яралый башлый.* Хезмәт даны

**ЯРАЛГЫ** *и.* 1) Кешедә һәм хайваннарда: организм үсешенең ана карынында яки йомырка эчендә була торган иң башлангыч чоры; эмбрион. *Ана карынындагы яралгы кеше кавеме үсешендәге төп баскычларны кабатлый.* А.Тимергалин. *Авырлы хатын грипп белән чирләп китсә, бу яралгының зарарлануына яисә бала төшүгә китерергә мөмкин.* Әлки хәбәрләре // Югары төзелешле үсемлекләрдә: орлык эчендә аталанганнан соң үсә башлый торган башлангыч организм. *Үсемлекнең яралгысы башлыча ясалгы тукымадан тора.* Биология. *Бодай үзлегеннән серкәләнгәндә, серкә күкәй күзәнәк белән кушыла, һәм үсемлекнең яңа яралгысы (орлык) барлыкка килә.* Фән һәм тел

2) *күч.* Берәр нәрсәнең башлангычы. *Аңа калса, илһам яралгысы барыннан да элек эшлисе эшнең кирәклеген тирән аңлауда, шуны күңел белән тоюда бит.* Г.Әпсәләмов. *Мин боларның барысына да яралгыда ук тамыр чабарга булдым!* А.Гыйләҗев

◊ **Яралгы хәлендә** Берәр нәрсәнең башлангычта, башында, әле үсеш алмаган, примитив булуы турында. *Татарча терминология исә яралгы хәлендә генә булып, терминнар, гадәттә, гарәби, фарси яки интернациональ алынмалар рәвешендә яшәп килә.* А.Тимергалин. *Шәһәрнең культурасы яралгы хәлендә икән – монысы безнең уртак бәлабез.* Р.Вәлиев

**ЯРАЛМА** *и. сөйл. к.* **яралгы** (*1 мәгъ.*)

**ЯРАЛУ** *ф.* 1) Карында яралгы барлыкка килү. *Шул бала ана карынында өч пәрдә сагында үсә, аннан соң дөньяга килә.* Р.Батулла

2) Туу; барлыкка килү. *Үз эченнән: «Кайчан, ничек яралып өлгерде бу шайтан балалары!» – дип әрнеп, өметсезләнеп уйланды [ул].* Г.Ибраһимов. *Үлемсезлек – гади нәрсә бит ул: Буын арты буын яралып, Яшәреп тә, һаман матурланып Мәңге яшәрбез без яңарып!* Ш.Галиев. *Уналтыда яралмаса, мәхәббәт егермедән соң килерме?* А.Гыйләҗев

3) Килеп чыгу; пәйда булу. *Утрау уртасында томаннан яралып алдына баскан теге карчык иде бу.* М.Кәбиров. *Берәр афәт яралмасмы?* Мәдәни җомга

4) Башлану, туу, ату (көн, таң тур.). *Кайчан таң яралып, көн яктыргач, падишаһ урыныннан торып тәхетенә утырды.* К.Насыйри. *Әле таң яралган гына була, ә идарәдә сине инде төрлесе төрле йомыш белән килгән берничә кеше көтеп тора...* В.Нуруллин

5) *күч.* Уй, фикер, караш, берәр хис туу, барлыкка килү. *Яз килә, яз, хисләр яңара, Яңа, якты уйлар ярала. Ташуларда ага чүп-чарлар, Барыр юлдан китә юк-барлар.* Ш.Галиев. *Нәфисәнең Рифатка карата булган мәхәббәте шулай яралып, көннән-көнгә зурая гына барды.* Ф.Яхин

**Ярала башлау** Яралу билгеләре сиземләнү

**Яралып бетү** Тулысынча яралу. *«Кешене маймылдан яралган дигән булалар, маймылдан түгел, дуңгыздан яралган ул. Яралып ук беткән булса әле...» – дип язган иде Нурдәүләт үзенең бер әсәрендә.* З.Мурсиев

**Яралып килү** Яралу процессында булу. *Җирдә яңа көн яралып килә – аяз, тыныч көн.* М.Маликова. *Ходаем, әле яралып кына килгән җан турында, үз сабыең турында шулай әйтергә ярыймы?!* Г.Әдһәмова

**Яралып кую** Кинәт яралу. *Егетнең күңелендә нindидер такмаза да яралып куйгандай итте ---.* А.Хәлим

**Яралып тору** Бертуктаусыз яки әледән-әле яралу; әле, хәзер яралу. *Күктә исә һаман үзгәреп, һаман яралып торган тормыш мисалында дәһшәтле бушлыкка сибелгән йолдызлар кабынган иде.* С.Шәмси

**Яралып яту** *сөйл.* Әле, хәзер яралу. *Ашыгырга Илсөярнең сәбәбе бар: ул үз карынында яралып ятучы баласының алдан беленүен, дуслары күзенә күренүен теләми иде, шуңа күрә Фатихка бүлмә бирүгә үк язылышып, күченеп тә куйдылар.* Ф.Яруллин

**ЯРАЛЫ** *с.* **1.** 1) Ярасы, җәрәхәте булган, яраланган, җәрәхәтле. *Таһиров, яралы арысландай үкереп, читлек эчендә йөри.* А.Гадел. *Яралы бармак кая сузсаң да бәрелүчән була бит.* А.Гыйләҗев

2) *күп.* Борчуы, газабы булган. *Кадриянең яралы йөрәгенә Җәмил дә тоз сибә ---.* В.Имамов

**2.** *рәв. мәгъ.* Яра алып, җәрәхәтләнеп. *Яудан коры кайтканчы, яралы кайт.* Мәкаль

**3.** *и. мәгъ.* Яраланган кеше. *– Их, туганкай, – диде яралы, яңадан фронт хәлләренә күчеп, – әгәр син анда эшләр ничек булганын белсәң иде!* Г.Әпсәләмов

**ЯРАЛЫШ** *и.* Яралу, барлыкка килү процессы; яралу вакыты, яралу моменты. *Безне кемнәр чагыштырсын, Ничек үлчәп, ни юрап? Яралышта ук аерма: Мин – хатын-кыз, син – ир-ат.* К.Булатова. *Кешенең яралышы, дөньяга туувы – үзе могҗиза.* Г.Хөсәенов

**ЯРАМСАК** *с. диал. к.* **ялагай**. *Ярамсак кеше*

**ЯРАМСАКЛАНУ** *ф. диал. к.* **ялагайлану**. *Укытучыга һичбер ярамсаклана белми [ул], нинди теманы кайчан сорасалар да, чатнатып җавап бирә.* А.Хәйретдинова

**Ярамсакланып алу** Бераз ярамсаклану. *[Ул] --- Ленинград камалышын берүзе өзгәндәй әтәчләнеп һәм югары командование алдында ярамсакланып алырга булды, күрәсең.* А.Хәлим

**ЯРАМСАКЛЫК** *и. диал. к.* **ялагайлык**

**ЯРАН** I *и. фар.* 1) Уртак максат, караш, мәнфәгать, эшчәнлек нигезендә берләшкән затлардан берсе. *Сакчылар, Аттиланың яраннары басып торалар.* З.Хәким. *Бу кварталлардан тыш Батыйның һәм аның яраннарының зурзур сарайлары тора.* И.Хуҗин

2) *күч.* Бай яки дәрәҗәле кеше тирәсендәге һәр сүзен үтәргә әзер торган куштан, иярчен. *Ә син яраннарың берлән җырлый-җырлый аракы чөмереп утырдың.* А.Гыйләҗев

**ЯРАН** II *и. гр. к.* **ярангөл**. *Аның тирәсендә гөләп, лалә, канәфер, яран, нәркис түтәлләре тезелешеп киткән.* В.Имамов

**ЯРА́НГА** *и. чук.* Кайбер төньяк халыкларында болан тиресе белән капланган, гөмбәз яки конус формасындагы күчереп йөртелә торган торак. *Төнге салкын тынлыкта сопкадагы бәс кунган ярангалар очлы башлы кар өемнәрен хәтерләтә.* А.Мифтахетдинов.– *Сез монда ярангада яшәгән кебек көн итәсез икән, – диде Зуфирә, тиреләргә ишарәләп, һәм өстәл янындагы уңайсыз урындыкның кырына гына утырды.* М.Маликова

**ЯРАНГӨЛ** *и. бот.* Яранчалар семьялыгыннан хуш ис килә торган яфраклы, ак, ал, кызыл төстәге чәчәк ата торган төрләре булган декоратив үсемлек; *русчасы:* **герань**. *Тәрәзә төбендәге ярангөлнең кып-кызыл чәчкәләре кояшка үрелде сыман.* Г.Әдһәмова. *Сыерчык оясы зурлык өйдә, тәрәзә төбендә ярангөл үстереп, сыер асрап, гади авыл хатыны булып яшисе килә...* К.Кара

**ЯРАР** *мод. сүз* **1.** Ризалашуны, килешүне, хуплауны белдерә. *Ярар, хәзергә бу катлаулы нәрсәләрне куеп торыйк, яме?* А.Тимергалин

**2.** *кис. мәгъ. к.* **ярый 2**. *Мәче баласы хәтле бер кәҗә бәрәне генә булса да ярар иде әле.* А.Алиш.

**ЯРАРЛЫК** *с.* **1.** 1) Нәрсәгә дә булса яраклы; ярый торган. *Урман кисүчеләр бензопилалар белән кораб мачталарына ярарлык төз наратларны аудара торган делянка посёлоктан биш чакрымнар эчтәрәк.* А.Хәсәнов

2) Дәрәҗәсенә туры килгән, тиеш булган; лаек. *Болары миңа ярарлык эшләр түгел.* В.Нуруллин

3) Урта дәрәҗәдәге, бер ягы белән дә аерылып тормаган; начар түгел, канәгатьләндерерлек. *Болай товары ярарлык икән.* Т.Гыйззәт. *Ярарлык булган бу.* А.Гыйләҗев

**2.** *и. мәгъ.* Берәр нәрсәгә яраклы булган зат яисә әйбер. – *Нәрсәсе ярасын, – диде ул, кинәт калкына төшеп. – Ярарлыгы юк! Чүп!* А.Гыйләҗев. *Теләсә кая илт бу әрәмтамагыңны, эшкә ярарлыклары калсын.* Кызыл таң

**3.** *хәб. функ.* Мөмкин, канәгатьләнерлек. *Боларны кайда куйсаң да ярарлык.* Т.Гыйззәт. – *Минем торган урыным хәзергә бик ярарлык, – диде Мәдинә.* М.Хәсәнов

**ЯРАТАШ** *и. к.* **ачуташ**. *Аны яра ташы, яраташ та дигәннәр, чөнки ул дезинфекцияләү һәм яраларны төзәтү хасиятенә ия.* А.Тимергалин

**ЯРА́ ТАШЫ** *и. к.* **ачуташ**. *Алар яралы Тотыш янына килделәр, аның киселгән беләген карадылар; яраны яхшылап салкын су белән юдылар да киселгән иткә яра ташы кырып салдылар, шуннан соң беләкне ныгытып бәйләп куйдылар.* Н.Фәттах

**ЯРАТУ** I *ф.* 1) Берәр кешене яки нәрсәне бик якын итү, үз итү; аңа тартылу; кабул итү. *Дөресен әйтим: киленне башта яратмаган идем, хәзер күз ияләште.* А.Алиш. *Сөләйман Хуҗа Болгар илен бик яраткан, шуның өчен кире Мәккәгә кайтып китмәгән.* А.Тимергалин

2) Хөрмәтләү, ихтирам итү. *Сәнгать дөньясында бик күпләр аны яраталар, бик күпләр яратмыйлар. Яратмаганнар аннан куркалар – бусы табигый.* А.Гыйләҗев

3) Икенче җенестәге кешегә мәхәббәт тоту, сөю. *Яратам икән мин сине, сөям икән... Чамасыз, шашып яратам икән.* А.Гыйләҗев. *Яраттымы ул Гөлнарны, әллә ияләшү генә идеме – ни генә булмасын, шатлык-борчуны бергә бүлешкән бердәнбере иде бит ул аның.* А.Әхмәтгалиева

4) Берәр нәрсә белән мавыгу, теләп, күңел биреп шөгыльләнү. *Әй, яратмыйм да инде шул тарих дәресен.* А.Әхмәтгалиева. *Мин әле тагын кешеләрне тыңларга, аларның тормыш тәҗрибәләре белән уртаклашырга, шул турыда мәкаләләр дә язарга яратам.* А.Нәҗми

5) Берәр нәрсәне ошату, шуңардан канәгатьлек тою. *Мин март башын бик яратам...* А.Гыйләҗев. *Беләсең бит, мин акчаны бик яратам.* А.Нәҗми. *[Туй балдакларын] Кавышу сәгатьләрен теләп торсын дип, егетнең яратып кигән костюмы кесәсенә салып куйдылар.* А.Хәйретдинова // Нәрсәгә булса да һәвәс булу, тәмен ошату. – *Шулай да иң яраткан ризыгыгыз нәрсә? – дип сорадым.* А.Хәсәнов // Берәр нәрсәгә гадәтләнү, еш, бик теләп яисә сизмәстән дә башкару. *Сез, кечкенә кеше, кызарга бик яратасыз икән.* А.Алиш. *Әткәй шушы җырны көйләргә бик ярата иде...* А.Гыйләҗев

6) Хуплау, берәр нәрсәне дөрес дип табу, ризалашу. *Сөйләгәндә бүлдергәнне яратмыйм мин...* А.Шамов. *Марат машиналарын соры дигәнне яратмый, юеш асфальт төсе, дияргә куша.* А.Гыймадиев

7) Ихтыяҗ тою, кирәксенү, таләп итү. *Акча санауны ярата.* Әйтем. *Суалчаннар дымлырак җирне яраталар.* А.Гадел

**Ярата бару** Торган саен ныграк ярату. *Ә мин сезне аның саен ныграк ярата барам.* В.Нуруллин. *Әй Бәдертдинкәем, сине көннән-көн ныграк ярата барам.* Н.Әхмәдиев

**Ярата башлау** Ярату билгеләре сизмләнү; яратырга тотыну. *Шуның белән егетнең берәр җирен сыйпасаң, ул егет кызны тәкатьсез булып ярата башлый икән.* А.Тимергалин. *Соңгы араларда алар бер-берсе белән сөйләшеп утырырга ярата башладылар.* А.Нәҗми

**Ярата бирү** Бернигә карамый ярату; һаман ярату. *Бәлки ул, әгәр мине чын күңелдән яратса, гафу итәр, элеккечә үк ярата бирер.* А.Расих. *Ярата бир, әйдә, үз-үзеңне! Аңларсың да – ләкин соң булыр.* К.Фатыйхова-Бәдретдинова

**Ярата төшү** Күбрәк ярату. *Төрле видео, магнитофон, патефоннарга караганда, музыканы гади авазларга таркатып бетерә торган шарманканы ярата төшә иде ул...* А.Тимергалин. *Тик син егетне кулдан ычкындырма: шаула, скандал яса, кычкыр, таләп ит, ирләр шундый мөстәкыйль хатыннарны ярата төшә.* Т.Галиуллин

**Яратып бетерү** Бик нык ярату; яратмый башлау. *Эшен яратып бетерми*

**Яратып йөрү** Озак вакытлар ярату. *Биш-алты ел үзеңне яратып йөргәнем өчен, бер кечкенә генә теләгемне үтә әле, ичмасам.* В.Нуруллин

**Яратып килү** Күптәннән әлегәчә ярату. *Математика, физика, химия, әдәбият дәресләрен гел яратып килдем.* Ә.Давыдов

**Яратып китү** Тора-бара ярату. *Дөрес, ул Себердә бер хатын белән яшәп караган, ләкин яратып китә алмаган.* Н.Көбәш

**Яратып кую** Көтмәгәндә ярату. *[Геолог:] Бәлки, яратып та куярсыз... Алдагы көннәрдә, дим?* А.Гыйләҗев

**ЯРАТУ** II *ф.* Барлыкка китерү, юктан бар итү; тудыру (гадәттә, Аллаһы Тәгалә тур.). *И Мөхәммәд, Хак Тәгалә яраткан адәм балаларыннан син иң бәхетлесе.* Ф.Яхин. *Табигать-анабызны әйтәм әле, кызылканат дигән бу балыкларны ай-һай матур итеп яраткан!* А.Хәсәнов

**ЯРАТУ** III *ф.* 1) Берәр нәрсәне кирәкле үлчәмгә, формага җиткерү, туры китерү, бер нәрсәне икенчесенә ярарлык итү. *Детальләрне бер-берсенә ярату*

2) Кирәклесен, туры килерлеген сайлап алу, туры китерү. *Гараж йозагына ачкыч яратып, велосипед урлап чыкканнар!* А.Гыйләҗев

**ЯРАТУ** IV *и.* Мәхәббәт, гыйшык, сөю. *Ярату, мәхәббәт – бөек хис, әлбәттә.* А.Әхмәдуллин. *Синең эчеңдә ярату хисе балкый.* А.Хәсәнов

**ЯРАТЫЛУ** *ф.* төш. юн. к. **ярату** II. *Мөсафир булып яратылган кеше Ватанын табар микән?* А.Тимергалин. *Кеше дөньяга парлы итеп яратылган.* А.Мансуров

**ЯРАТЫЛЫШ** *и.* 1) Яратылу күренеше; яратылу моменты. *Җир яратылышыннан алып бүгенге җилкапкалы дәверләргә кадәр араны авазларда сурәтләп биргән инженер, көне буе уйнап арган сабый шикелле, сулышын да чыгармый йоклый иде.* М.Галиев

2) Кешенең холкы-фигыле, табигате, фитърәте. *Яратылышы белән зыялы һәм әдип зат булса да, шушы табигый барлык-булганлыкны дөньялыкта раслар өчен, аңа биниһая көч, хезмәт куярга --- туры килде.* Р.Фәйзуллин

**ЯРАТЫШУ** *ф. урт. юн. к.* **ярату** I. *Без бит бер-беребезне яратышабыз.* В.Нуруллин. *О-о... ничек яратышалар иде алар!* А.Тимергалин. *Шәүкәт абый белән, мәсәлән, гаҗәп нык яратыша, хөрмәт итешәсез.* Э.Шәрифуллина

**Яратыша башлау** Яратышу билгеләре сиземләнү. *Безнең яратыша башлау да кызык кына килеп чыкты бит, абзый кеше.* Д.Салихов. *Сез... Сез яңадан яратыша башладыгызмы?* М.Кәбиров

**Яратышып йөрү** Озак вакытлар яратышу. *Мәрьям туташны, үзе белгәннән бирле яратышып йөргән вә кабергәчә бергә булырга вәгъдә куешкан яры Зыяга бирмичә, икенче бер егеткә биргәннәр.* Г.Ибраһимов. *Электән үк ул кыз белән яратышып йөргәннәр булып чыкты.* И.Юзеев

**Яратышып калу** Яратышырга өлгерү. *Соңга калып булса да яратышып калыйк!* Г.Каюмов

**Яратышып китү** Кинәт, уйламаганда яратыша башлау; тора-бара яратышу. *Яшьлегендә Сәүбән белән яратышып китүе дә шул серлелегеннән, хыялыйлыгыннан булгандыр.* Г.Гыйльманов

**Яратышып кую** Көтмәгәндә яратышу. *Берәрсе белән яратышып куйсагыз...* Г.Бәширов

**Яратышып тору** Гел яратышу. *Ир белән хатын бер-берләрен гел генә яратышып тормыйлардыр дип уйлыйм.* Ш.Камал

**ЯРА́У** I *ф.* 1) Берәр нәрсәгә файдалану өчен яраклы булу. *Анысы да эшкә яраган – чырымтадан киндерә ишкәннәр.* А.Тимергалин // Нинди дә булса эш башкара алу. *Вак йомышка ярады инде.* З.Мәхмүди. *Сабан тоттым, печән чаптым, ат карадым... Атасыздан һәр эшкә иртә ярадым.* Р.Ханнанов

2) Яхшы булу, файдасы тию. *Мактәптә укыганда драмтүгәрәккә йөрү ярады.* И.Юзеев

3) Үлчәве, сыйфаты һ.б.ш. билгеләре белән туры килү. *Әнинең ак халаты Миңа таман, ярады.* Л.Шәех

4) Файдасы тию, кирәге чыгу. *Арада бик яхшы тавышлылар да бар икән – хорга кушылырга һәммәсе дә ярады.* Г.Ибраһимов. – *Зөбәйдә Чаллы ягына чыгып китте әле, кайчан кайтыр – билгесез, – дигән шомлы җавап егет күңелендәге газап утын көчәйтергә генә ярады.* В.Имамов

5) Билгеле нормаларга, кагыйдәләргә туры килү. *[Шафика:] Сөйләргә яраган хәтлесен очрашкач сөйләрмен.* А.Гыйләҗев. *Ә мин зур җинаятькә якын, бер дә ярамаган эш эшләгәнмен икән.* А.Хәсәнов

6) *хуплм.* Кемгә дә булса ошарга тырышу, аның алдында яхшатлану. *Туры әйткән туганына ярамаган.* Мәкаль. *Соңыннан байга тәрилкә тотып, ялынып-ялманып йөреп, байга ярады.* Г.Камал

7) Әйбәт тәэсир итү, уңышлы нәтиҗә бирү, килешү. *Дару авыруга ярады* // *юкл.* Начар тәэсир итү, зыяны тию. *Ялан-аяк йөрү ярамады – томау алды*

**Ярап бетү** Тулысынча, бар яктан ярау. – *Тик син ярап бетәрсең микән, белмим... – диде Вафа.* М.Галәү. *Мин сиңа ярап бетә алмадыммыни?* М.Маликова

**Ярап китү** Билгеле бер вакыттан ярау. *Аның атасы, авылдан самавырчы малай булып килеп, тора-тора абыстайга ярап китеп, егерме-утыз ел эчендә миллионлы чәй фирмасының хуҗасы булган Борһанетдин абзый түгелме соң?* Г.Исхакый

**Ярап кую** Көтмәгәндә ярау. *Шул киңәш хәзер ярап куйды!..* А.Гыйләҗев. *Мыеклы агайның арыш ипие белән тозлы салосы шунда бик тә ярап куя.* А.Тимергалин

**Ярап тору** Әлегә, вакытлыча ярау. *Бәясе арзан булганлыктан, җигеп йөрергә ярап торыр дип, шул алашага тиендек.* Г.Гомәр. *Сирәк булса да, чиертә балык – гади елга чабаклары, әлбәттә, ваграклар инде, әмма шулпа өчен ярап тора...* А.Тимергалин

**Ярый башлау** Ярарга тотыну. *Бер яктан, мин сабагымны яхшы белсәм, икенче яктан, аз булса да, йорт хезмәтләренә дә ярый башладым.* Г.Тукай. *Ләкин тормышлар авыр булганга, эшкә ярый башлагач та, әтисе аны үзе белән такта ярырга алып китте.* Г.Әпсәләмов

**ЯРА́У** II *с. диал.* 1) Көч, сәләт, акыл һәм башка яктан җитлеккән, камил. *Моннан соң акыллырак, яраурак була белергә кирәк.* А.Гыйләҗев

2) Чабышка махсус әзерләнгән. *Ярау ат*

3) Егәрле, җитез; тук һәм елдам (ат тур.)

4) Гайрәтле, таза һәм нык, көчле. *Кызның чибәре ярау егеткә.* Әйтем. *Мин сугыш чукмары түгел, аннары Гыйльфан төптән таза чыккан ярау егет иде.* Р.Низамиев

5) Яхшы сыйфатлы яки югары сортлы, калорияле азык. *Җир алмасы [бәрәңге] хәзер инде ярау азыкка әйләнеп бара.* М.Гали

◊ **Ярау алдыру** *к.* **яраулау**. **Ярау алу** 1) Авыр эштән, ерак юлдан соң хәл алу, ял итеп көч туплау, тыну. *Бер көн эштән туктагач, карт-корылар йоклагач, урак өсте станда ярау алып ятканда, Миңлекәйне күрдем мин.*

Ф.Бурнаш. *Бүлмә җиләслегеннән җанга-тәнгә аз булса да ярау алдым.* Б.Камалов; 2) Чабышка махсус әзерләнү (ат тур.). **Ярау яру** Үз дигәнен булдыра торган булып китү; үткенләнү, шомару; усаллану; азау яру. *Ярау ярган егетләр кирәк бу эшкә*

**ЯРА́У** III *с. диал.* **1.** Салкынча, җиләс. *Йокыны китерә торган тынлык. Татлы төшләр күрә-күрә, ярау урында изрәп кенә йокларлык.* Казан утлары

**2.** *и. мәгъ.* 1) Салкынча, җиләс вакыт. *Иртәнге ярауда, чәй янында изү чишеп изелеп утырганда, гөмбә, дип, карлыган, дип, кыш та җитәр, дип, хатын да мырламаса!..* А.Гыйләҗев. *Һава талгын, кичке ярау төшкән ---.* Р.Маннапов

2) Салкынча һава, җиләслек. *Тышта, ниһаять, һава җиләсләнгән, таулардан тансык ярау – салкынча сафлык иңә.* Т.Әйди

**ЯРАУЛАНДЫРУ** *ф.* Атны ат чабышына, чабышкы булырга әзерләү, ярау алдыру. *Бераздан мин Каракошны ярауландыру эшенә керештем. Җикмәдем, менгегә генә тотарга булдым.* М.Хәсәнов // Үгезне ярышка әзерләү; усалландыру. *Бездә атлар чабыштыру, юртаклар узыштыру булса, анда махсус тәрбияләнгән, ярауландырган сөзгәк үгезне күз алдында кызыл җәймә җилпеп котырту икән.* Х.Камалов // Чабыштан соң (атны) акрын гына йөртеп ял иттерү, суыту

**ЯРАУЛАНУ** I *ф.* 1) Чабышка әзер булу, ярау алу (ат тур.)

2) *к.* **ярау яру**. *Егет ярауланган*

**Ярауланып тору** Даими ярауланy. *Айгыр үзе дә сизә бугай: бернәрсә капмый, әллә нәрсә көткән кебек, еракка карап, гел ашкынып, ярауланып тора.* Г.Ибраһимов

**ЯРАУЛАНУ** II *ф. диал.* Салкынчалану, көн кызуы басылу. *Төн уртасында, калай суынып, вагон эче яраулангачкына изелеп йокыга китте Фазыл.* К.Кәримов

**ЯРАУЛА́У** *ф. диал.* 1) Атны чабышка әзерләү. *Атны сабан туена яраулау*

2) Кызу йөргәннән яки ерак юлдан, авыр эштән соң, йөртеп, әкренләп суыту, тирен киптерү (ат тур.) // Гомумән хәл алу, ял итеп көч туплау

**ЯРАУЛЫ** I *с.* 1) Берәр нәрсәгә ярый торган, яраpлык, кулай. *Суы әле дә чәйгә яраулы.* М.Вәлиев. *Бу сабаннарның берсе дә яраулы түгел, – берсенең тәгәрмәче ватык, икенчесенең күчәре сынык, өченчесенең төрәне төптән каерылып чыккан, – алар белән ике сәгатьтән артык азап.* Ф.Мансуров. *Бер шәлнең акчасы Фәридунның чиренә яраулы бер кап даруга таман гына була.* Сөембикә // Туры килгән. *Һәркем күңеленә яраулы ачкыч таба алабызмы?* Казан утлары

2) Таман, чак. *Роберт Миңнуллинның төп максаты-юлы да шунда: баланың иртәгесе көнен истә тотып, «үсә төшкәч тә кияргә яраулы» кием алган кебек, ул тәэсир-тәрбия көче белән киләчәккә төбәлгән шигырьләр иҗат итә.* М.Вәлиев

**ЯРАУЛЫ** II *с.* Салкынча, саф. *Парторг сүзләре барыбер үзенекен итте. Эссе, бөркү көндә искән яраулы җил кебек.* Ә.Сәйфетдинов

**ЯРАУСЫЗ** *с.* 1) Ярамый торган, яраксыз; сыйфаты, дәрәҗәсе килмәгән. *Саф әле күңлең синең, һичбер бозык уй кермәгән, Пакь телең дә һич яраусыз сүзләр әйтеп күрмәгән.* Г.Тукай

2) *диал.* Җитлекмәгән, булдыксыз, юньсез. *Яраусыз кешегә сүз әйтсәң, ярыла-ярыла йортка [илгә] җәяр.* Әйтем

**ЯРА́ ҮЛӘНЕ** *и бот. к.* **бака яфрагы**. *Янәшәдә булган Маша апам тирән киселгән, кан аккан яраны күреп кычкырып җибәрде, зур гына яра үләне яфрагын өзеп ярага куйды.* Кама ягы

**ЯРА́ ЧҮПРӘГЕ** *и. сөйл.* Бинт

**ЯРАШЛЫ** *с.* Ярый, туры килә торган. *Сатучының үзендә аңа ярашлы подшипник булмады.* А.Гыйльми. *– Мин кызларымның тәрбиясенә катнашмыйм, чөнки минем тәрбия методларым хәзерге заманга ярашлы түгел, ярамый, – ди шул Ефимыч.* А.Гыйләҗев

**ЯРАШЛЫЛЫК** *и.* Ярашлы булу хәле, туры килүчәнлек. *Болай эшләү үзенең нәтиҗәлелеген һәм максатка ярашлылыгын күрсәтте.* Алга

**ЯРАШТЫРУ** *ф.* 1) Берәр нәрсәгә ярарлык итү, туры китерү. *Карак ачкыч яраштыра, ә алдакчы ялганлый.* Мәкаль. *Нинди дә булса берәр күңелсезлек көткән ирләр дә бөтенләй тик ятмыйлар, урындык-өстәл ватудан башка төрлерәк хәстәр дә күрәләр: балта, пычак, чалгы кайрыйлар һәм аларга җайлырак сап яраштыралар иде.* М.Галәү. *Шул текст эчтәлегенә яраштырып, көйләр дә иҗат ителә башлаган.* К.Гыйззәтов // Кемнең яки нәрсәнең дә булса таләпләренә, кагыйдәләренә җавап бирерлек итү, шуларга туры китерү. *Тик бөтен бәла шунда шул: кешеләр үзләренең яшәү рәвешләрен Җир-ана, табигать белән яраштырып кормыйлар.* С.Лашманчы

2) Көйләү, эшкә яраклы хәлгә китерү. *Нәҗми, винтовкасын яраштырып, көлү тавышы ишетелгән якка атып җибәрде.* Һ.Такташ. *Старшина, аратирә генә туктап, азимутны яраштыра да тагын кузгала иде.* Г.Әпсәләмов

3) Үзара бәйләнешкә кертү. *Нерв системасы аерым органнарның эшчәнлеген бер-берсе белән яраштыра.* Анатомия

4) Килештерү, дуслаштыру, татулаштыру. *Байлык яраштыра, ярлылык талаштыра, дип, юкка гына әйтмәгәннәр, күрәсең.* И.Гази. *Ә син аларны яраштырырга, килештерергә мәҗбүр буласың.* М.Кәбиров

**Яраштыра башлау** Яраштырырга керешү. *Композиторның гадәти шигырьгә күзе төшеп, җырга яраштыра башласа, андый кимчелек-артыклык күренә ул.* Ш.Галиев

**Яраштырып бетерү** Тәмам яраштыру. *Ахырга таба, язылa-язылa, кеше аны үзенә яраштырып бетергән.* Казан утлары

**Яраштырып йөрү** Әле, хәзер яраштыру. *Механизаторлар, пилорам кирәк дип, вал яраштырып йөриләр ---.* Ш.Галиев

**ЯРАШУ** *ф.* 1) Өйрәнеп, тәҗрибә туплап, үзләшеп китү. *Кем әйтмешли, моңарчы үзем яшәгән мохит торгынлыгына ярашкан булганмын, күрәсең.* А.Вергазов // Яраклашу. *Шуннан соң ул Патыйга яраша, аны күккә чөеп мактый башлады.* М.Галәү. *[Хөрмәтулла:] Заманалар үзгәрә тора... Җайлаша да, яраша да белергә кирәк...* А.Гыйләҗев

2) Ярау, туры килү; үзара бәйләнештә, гармониядә булу. *Бигрәк тә тирәюньдәге табигать хозурлыклары – мәһабәт калкулыклар, урман манзаралары белән һич тә туры килми, үзара ярашмый бу йортлар.* А.Вергазов. *Таштагы шәҗәрә «Шура» журналындагы текст (1915, № 7) белән яраша, ләкин яңа мәгълүматлары белән дә кызыклы.* М.Әхмәтҗанов

3) *лингв.* Сүзтезмәдә иярүче сүз ияртүче сүз белән бер үк төрдә, бер формада килү. *Шәкли грамматикада без җөмләне, ялганмалык табигатенә караганда, баш килештәге иягә бәйләнеп, аңа ярашып әйтелгән хәбәрдән гыйбарәт сүзләр тезмәсе, дип тәгъриф итәргә тиеш булабыз.* Г.Алпаров. *Типологик яктан, рус телендә, мәсәлән,*

*сан белән ачыкланган исемнәр килеш, сан белән төрләнәләр, ягъни сан саналмышы белән ярашып килә: два ученика, двух учеников, двум ученикам һ.б.* Ф.Хисамова

4) *лингв.* Сүздә я калын, я нечкә генә авазлар булу; сингармонизмга буйсыну. *Бер сүздәге авазларның калынлык, нечкәлектә бер-беренә ярашып әйтелүенә сингармонизм кануны дип әйтәләр.* Г.Алпаров

5) *күч.* Тынычлап, килешеп яшәү. *Килен белән кайнана башта ук ярашмадылар.* Н.Гыйматдинова

**Яраша бару** Торган саен ныграк ярашу. *Ләкин бу безгә зыян итми, Әнисә, чөнки безнең организмыбыз тышкы мохиткә үзеннән-үзе яраша бара.* Г.Әпсәләмов

**Яраша башлау** Ярашуга табан бару, ярашу билгеләре күренү. *Тәмам исенә килеп, хәлгә яраша башлаган Әнвәр немецның бер колонна артына посып атканын абайлап алды.* Х.Камалов. *М.Госманов, әлеге һәм башка төрле фикерләргә нәтиҗә ясап, аерым өзекләрне транскрипцияләп, «Җәмигыт-тәварих» җирле шартларга яраша башлаган Алтын Урда-Харәзем әдәби телендә язылган, дип белдерә ---.* Татар әдәби теле тарихы

**Яраша төшү** Бераз ярашу. *Тәмсезләшкәннән соң, ничектер, отыры бер-берең(ә) яраша төшәсең кебек.* Х.Камалов

**Ярашып бетү** Тәмам, тулысынча ярашу. *Чөнки кушма исемнәрнең гармония ягыннан авазлары бер-беренә ярашып бетмәгән булса да, басымнары, мәгънәләре ягыннан алар башка ялгыз сүзләр кебек әйтеләләр ---.* Г.Алпаров. *Ә уй-фикерләрнең әле заманына ярашып бетмәгән чагы икән.* Н.Гариф

**Ярашып җитү** Тиешле дәрәҗәдә ярашу. *«Инкыйраз»дагы бүгенге күзгә төзекле-төзексез җөмләләр, сүзләрнең үзара ярашып җитмәве, кайчагында урынсыз кулланылуы, гади сөйләм белән әдәби телнең буталуы... – боларга без күз йомарга тиеш булабыз ---.* А.Тимергалин

**Ярашып китү** Кинәт яки билгеле вакыттан ярашу. *Әмма берсе «Рамай»га, икенчесе «Әлдермеш»кә көйләп, ярашып китә алмыйча шактый газаплангач, ахырда туктаганнар.* Ф.Яхин. *Ул кышка, салкыннарга чыдам тугыз алмагач сорты китереп чыгарган, төньякта шул алмагачлар гөрләп торып үсеп, ярашып киткән.* Р.Кутуй

**Ярашып тору** Даими ярашу; әле, хәзер ярашу. *Өстендәге ак киндер күлмәге аның ак йөзенә ярашып тора төсле.* С.Поварисов. *Ул бурсык малаеның исеме дә үзенә бик тә ярашып тора: Бурлас!* Р.Батулла

**ЯРАШЫК** *и.* **1.** Чабышка өйрәтелгән ат. *Хуҗасының һәр хәрәкәтен тоеп барган ярашык шундук юыртып китте.* С.Зыялы

**2.** *с. мәгъ.* Чабышка өйрәтелгән. *Ярашык аттай ярсынган, Аргымак аттай типсенгән Аргыннарның башы идең ---.* Дастан

**ЯРӘШҮ** *ф.* Ата-анасыннан ризалык алып, кызны кияүгә алырга килешү. *Алар инде ярәшкәннәр, туй, никах хакында сөйләшү булмаса да, алтын балдакларга кадәр алып куйганнар.* Г.Гыйльманов

**Ярәшеп йөрү** Әле, хәзерге вакытта ярәшү. *Казан байлары арасында һәркемгә билгеле мәшһүр бай Әхмәди Хәмитов үзенең Хәдичә исемле кызын йөз мең сум көмеш акча белән кияүгә биргәнлектән, Муса Салихов шул туташны кәләшлеккә ярәшеп йөри.* З.Бигиев

**Ярәшеп кую** Алдан ярәшү. *Гадәт буенча, апам белән мине, тугач ук, әти үзенең ямчы дус-аркадашларының улларына ярәшеп куйган.* Ф.Сафин

**ЯРГАК** I *и.* **1.** 1) Ярылган бүрәнә. *Сәке такталарын, дөресрәге, бүрәнә яргакларын ком белән ышкып юдык.* И.Салахов

2) Ярылып киткән урын. *Бүлбесендә күрән төстәге таплар, яргаклар күренә.* Татарстан яшьләре

**2.** *с. мәгъ.* Ярылган. *--- бу учреждениене, Урта гасыр кальгалары көнләшерлек итеп, яргак бүрәнәләрдән өйгән ике метр ярымлы тоташ койма белән әйләндереп алганнар ---.* А.Тимергалин

**ЯРГАК** II *и. диал. сөйл.* **1.** 1) Артык күп сөйләргә, мактанырга яратучан кеше

2) Кайнаган сөт өстенә утырган куе яры, элпә. *Сөт өстендәге яргакны яратмау*

3) Төге, йоны коелган тире, төксез тире

**2.** *с. мәгъ.* Йонсыз тиредән эшләнгән. *Ялгыз атлы ярышчы, Яргак тунлы көрәшче.* Әйтем

**ЯРГАЛАНУ** *ф.* 1) Күп җирдән ярылу, ярыклар арту. *Кайчандыр шарлама суы җыелып торган казан кипкән, кояш нурларында телем-телем ярганып, крокодил тиресенә охшап калган иде.* Ф.Шәфигуллин. *Бөтен өмет сөремләнгән, яргаланган...* Р.Фәйзуллин

2) Салкыннан, эсседән, авыр физик эштән һ.б. сәбәпләрдән яралар хасил булу. *Куллары яргаланган, бер бармагы кәкре, бер күзе аклы, үзе һәрвакыт атларның аналарын сүгә...* Ш.Камал. *Яңаклары эчкә баткан, иреннәре күеп яргаланган.* Г.Әпсәләмов

3) *күч.* Картаеп юл-юл булып җыерчыклану (тире тур.). *Бабай зур гәүдәсе, киң җилкәсе, күкрәккә төшкән ак сакалы, җыерчыкланып яргаланган карт йөзе, басынкы кыяфәте белән килеп керде.* Г.Ибраһимов. *Карт инде, бите яргаланып, кояшта каралып, җилдә каешланып беткән ---.* Р.Максудов

**Яргалана башлау** Яргалану билгеләре күренү. *Аннары радиация нурлары тәэсирендә уала, яргалана башлый.* Т.Әйди. *Хәтта сызадагы күрәннәрне, аксыргакларны да сары тутык каплаган, аларның төбендәге су кибеп, саз гына калган, шәрәрәк урыннары яргалана ук башлаган.* Ф. Садриев

**Яргаланып бетү** Бик нык яргалану. *Аның яргаланып беткән сөялле бармаклары сизелер-сизелмәс кенә калтыранды.* А.Гыйләҗев. *Наташаның борчулардан агарынган йөзенә нур кунды, ә яргаланып беткән иреннәре туктаусыз дога сүзләрен кабатлады.* А.Мансуров

**Яргаланып калу** Ахырда яргаланган хәлгә килү. *Алар, бер-берсенә бәйләнгән кебек, Акбүре авылының үрге ягына чыктылар, язгы су төшкәндә убылып, яргаланып калган ерганак-ярлар янына килеп чыктылар.* Г.Гыйльманов

**Яргаланып китү** Кинәт яргалану; бераз яргалану. *Миләүшәнең учы яргаланып киткән, аннан туктаусыз кан саркый иде.* Сөембикә. *Житлеккән камыр, табага салгач, яргаланып китәргә тиеш – кабарып җиткәнен шуннан беләсең.* Безнең гәҗит

**Яргаланып тору** Даими, еш яргалану; әле яргалану. *Телдәге калын кунысклар, бигрәк тә тел төбе тирәсендә яргаланып торса, ашказаны-эчәк тракты авырулары башлану билгесе.* Әлмәт таңнары

**ЯРГАЛА́У** ф. 1) *кбт. форм. к.* **яру**. *Аның сабагын яргалап, яфракларын берәм-берәм йолыккалап, чәчкәсентаҗын, күзәнәген-тамырын аерымаерым тезеп салганда, аның хуш исе дә, яме дә калмый...* А.Гыйләҗев

2) Салкын, җил, физик эш тәэсир итеп, күп яралар хасил булуга китерү.

*Кулларыңны яргалаган җилләр, ул синең йөзеңә нур биргән, алсулык бүләк иткән кояш.* Д.Каюмова

3) *күч.* Бик күп җыерчыклар, буразналар хасил итү. *Әнә ике яңагы да эчкә суырылган, күз төпләрен эреле-ваклы җыерчык яргалаган.* В.Имамов. *Калын тупас кайрыларын тирән җыерчыклар яргалаган.* Д.Булатова

4) Кайчакта, сирәк кенә яру белән мәшгуль булу. *Газинур, моңарчы да такта яргалаган булганга, эшнең рәтен белә иде.* Г.Әпсәләмов

**Яргалап бетерү** Бик нык яргалау. *Кашына-кашына, бөтен тәнне яргалап бетердем бугай инде.* Г.Каюмов. *Җамал, җил ашап яргалап бетергән иреннәрен дерелдәтеп, инәлүле тавыш белән: «Сорама, кызым», – дияр иде.* А.Әхмәтгалиева

**Яргалап җибәрү** Бераз яргалау. *Кискән урынны бераз яргалап җибәрәбез, сабак очының кайрысын кубарабыз.* Сөембикә

**Яргалап ташлау** сөйл. Көтмәгәндә, бик тиз генә яки аннан-моннан яргалау. *Яланөс кенә утын яргалап ташладым; кызып китеп, Рәхимҗан бабайларга барып кердем, көздән бирле ишегалларын тарыктырып, күзгә кереп яткан карама түмәрләрен ваклап, лапас астына ташып өйдем.* А.Гыйләҗев. *Мәгъфия апа, дигән булып, үзеңнең вакытың юктыр, дигән булып, суын да кертеп бирде, утынын да яргалап ташлады ---.* Н.Фәттах

**Яргалап тору** Әледән-әле яисә даими яргалу; әле яргалау. *Салкын караңгылыкны яргалап торган корыч, бакыр катыш зәңгәрсу кызыл утлар, ыржайган тешле үлем тырнаклары төсле, җирнең күкрәген кармаштырып кара канга буйый иделәр.* Ш.Камал

**Яргалап ыргыту** *сөйл. к.* **яргалап ташлау**. *Кереп, бу түмәрләрне уңлысуллы яргалап ыргытасы булыр...* А.Гыйләҗев

**ЯРГЫЧ** *и. махс.* 1) Бүрәнәне пычкылап буйга яра торган җайланма, станок; пилорам. *Әле генә яргычтан чыгарылып шомартылган алтышар метрлы нарат такталарны сузып салган өстәлләрдә сый-нигъмәт авылча мул иде.* М.Маликова

2) Каты материалларны төеп, ышкып яки башка юл белән ваклый, яра торган җайланма; *русчасы:* **дробилка**. *Хатын-кызның күлмәк-ыштанга яшереп, бәләкәй капчыкка салып арыш алып кайтканын, аны яргычта ярып ашаганнарын; шул урланган орлыкны тентеп, бичара аналарны сигезәр елга төрмәгә утыртканнарын өлкән буын кешеләре белә.* Р.Хәбибуллина. *Әллә син мәнә бу тегермәнне, яргычны кору бик җиңел булгандыр дип уйлыйсыңмы?* Р.Вәлиев

**ЯРГЫЧЧЫ** *и.* Яргыч җайланмада, станокта эшләүче кеше. *Яргыччы Җәгүрдән качып, Кирилловлар тозагына килеп капканыңны аңламыйсыңмыни әле?* А.Гыйләҗев

**ЯРД** *и. ингл.* Инглиз үлчәмнәр системасында 91,44 см га тигез булган төп озынлык үлчәү берәмлеге

**ЯРДӘМ** *и. фар.* 1) Кемнең дә булса эшен, хәлен җиңеләйтү өчен башкарыла торган гамәл, булышлык. *Бу күренештән Галя нишләргә белмәде: кычкырыргамы, ярдәм чакырыргамы?* А.Алиш. *Тукта, бәлки, минем тагын да берәр ярдәмем кирәктер?* А.Хәлим

2) Кем өчендер бирелә торган ниндидер әйберләр, акча, техника, азык-төлек һ.б.ш.; иганә. *Акчалата, матди ярдәм. Дәүләт ярдәме*

3) *мед.* Авыртуны басу, авыру яки гадәттән тыш хәл сәбәпле үлемнән коткаруга юнәлтелгән чаралар. *Медицина ярдәме. Ашыгыч ярдәм. Җир тетрәүдә зыян күрүчеләргә ярдәм*

◊ **Ярдәмгә килү** *к.* **ярдәм итү**. *Без ярдәмгә килергә тиешбез.* А.Алиш. *Каратаев миңа ярдәмгә килде.* А.Тимергалин. **Ярдәм күрсәтү** *к.* **ярдәм итү**. *Ә авылда больница булса, авырый башлау белән барыр иде дә, авыруы көчәйгәнче, врач аңа тиешле ярдәмен күрсәтеп өлгерер иде.* В.Нуруллин. *Мин инде килмәкче, аны кардан күтәрмәкче, кулдан килгән ярдәмемне күрсәтмәкче идем.* А.Хәсәнов. **Ярдәм кулы сузу** *к.* **ярдәм итү.** *Бу дөньяда Азатка ярдәм кулы сузган тагын бер изге җан – тузганактай ап-ак чәчле алман карчыгы була.* А.Тимергалин. *Гаҗизлектән, чарасызлыктан берьялгызым бәргәләнәм, сугылам, кем дә булса ярдәм кулы сузмасмы дип як-ягыма каранам – сыйныфташларым да, укытучылар да, күзләрен читкә алып, битараф йөз белән янымнан үтеп китәләр.* А.Әхмәтгалиева

**ЯРДӘМЕНДӘ** *бәйл.* Ниндидер гамәл берәр нәрсә файдаланып үтәлүен белдерү өчен кулланыла; ярдәме белән. *Бу ике яклы элементә электр (яшен) чаткысы ярдәмендә тормышка ашырылган.* А.Тимергалин. *Оригинал-макет JahatTM программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.* А.Әхмәтгалиева

**ЯРДӘ́М ИТҮ** *ф.* 1) Нәрсәдер эшләгән кеше белән шул эшне бергәләп эшләү; булышу. – *Кил әле, кил, мин әзерләгән бал савытын да күреп китәрсең, кайбер җирләрен төзәткәлисе бардыр, бераз ярдәм дә итәрсең, – дигән.* А.Алиш

2) Акчалата, мал яки башка нәрсәләр биреп, авыр хәлдән чыгару, чыгарырга тырышу. *Өйләре янган кешеләргә әйберләтә ярдәм итү*

3) Үз көчен башка берәүгә яхшылык эшләү өчен куллану. *Суга батучыга ярдәм итү*

4) Медицина ярдәме күрсәтү. *Табиблар вакытында ярдәм итмәсәләр, үлүе ихтимал иде*

5) Файдасы булу, килешү. *Дару ярдәм итмәде*

**ЯРДӘ́М КЫЛУ** *ф. иск. к.* **ярдәм итү**. *Мин шуны савап дип беләм вә шуңар күрә, сәламәтлегем никадәр мөмкинлек бирмәсә дә, шул юлда иҗтиһад итәм, вә рәфикам да гадәттән тыш бер сурәттә ярдәм кыла, миңа кул тотышадыр.* Г.Бубый. *Күңелебез пакь, ниятебез ак, ясаган иям безгә ярдәм кылса кирәк...* Г.Ибраһимов

**ЯРДӘМЛӘШҮ** *ф.* 1) Бер-береңә ярдәм итү, булышу. *Дөньяның бар авырлыгы, кешеләрнең бар явызлыгы, бар кайгы-хәсрәте әнә шул кар астында күмелеп калган да, моннан соң алар үзара гел аңлашып, ярдәмләшеп кенә яшәрләр, бәхетле булырлар шикелле тоела.* В.Нуруллин

2) к. **ярдәм итү**. *Гөлбануның анасы Фәтхия карчык та үзенең бердәнбер кызы өчен барлык көче белән тырыша, ярдәмләшә иде.* Г.Ибраһимов. *Һөҗүм башлангач, пехотасына артиллерия һәм миномёт уты белән ярдәмләшә.* З.Зәйнуллин

**Ярдәмләшә башлау** Ярдәмләшергә тотыну. – *Сәгыйдә! – диде карчык вә урыныннан торды да кызына өс киемнәрен салырга ярдәмләшә башлады.* Ш.Камал. *Күчем ханнан кала татар дәүләтендә икенче дәрәҗә урында торган кешенең үзе белән болай аралаша, ярдәмләшә башлавы Ермакны бераз шикләндерсә дә, ул җибәргән ризыклар казакларга бик ярап куйды ---.* Ф.Бәйрәмова

**Ярдәмләшеп бару** Даими ярдәмләшү. *Монда хәлфә, шәкерт – һәммәсе кулга кул биреп, ярдәмләшеп барырга кирәк...* Г.Ибраһимов

**Ярдәмләшеп тору** Һәрвакыт ярдәмләшү. *Үзем кураторы булырмын, кирәк чакта ярдәмләшеп торырмын!* Р.Сәгъди. *Кыш көне кар көрәү, өлкән яшьтәге әби-бабайларга тирес чыгарышу, язларын бакча казышу, утын кисү, яру дисеңме – бер тартынмый ярдәмләшеп торды егетләр.* А.Хәйретдинова

**ЯРДӘМЛЕ** *с.* Ярдәм итүчән, ярдәмчел. *Бер-берегезгә ярдәмле булыгыз.* М.Мәһдиев. *Алар – киң күңелле, мохтаҗларга ярдәмле, тырыш, булган кешеләр.* Г.Галиева. *Димәк, тормышыгызда яхшы кешеләр – миһербанлы, ярдәмле кешеләр дә очрагандыр...* Р.Вәлиев

**ЯРДӘМЛЕК** *и.* **1.** 1) Уку-укыту процессында дәреслектән тыш кулланыла торган ярдәмче китап яисә берәр әсбап. *Айдарга килгәндә, дәресләрне Азат аңа үзе бирә – исендә калганнар буенча гына инде, чөнки бирedә уку ярдәмлекләре һәм дәреслекләр булмый.* А.Тимергалин. *Хәрби уку йортында татар телен өйрәнү өчен чыгарылган бу уку ярдәмлегендә халык иҗаты әсәрләренә дә зур урын бирелгән.* Л.Җамалетдинов // Берәр әйберне өйрәнүдә ярдәм итә торган нәрсә. *Бу төркем шигырьләр балаларга, әлифбаны өйрәнгәндә, зур ярдәмлек була ала.* Л.Минһаҗева

2) Инструкция. *Компьютер инструкцияләрен (ярдәмлеген), әлбәттә, сүзлек кулланып укый идем, һәм ул сүзлек укыган саен сирәгрәк кирәк була бара иде... З.Мифтахов*

**2.** *с. мәгъ. лингв.* Мөстәкыйль һәм тулы мәгънәләре булмаган (сүз төркеме тур.). *Компонентлар мөстәкыйль, ягъни үзләре генә кулланыла ала торганнарга һәм ярдәмлек компонентларга, шулай ук үзләре генә кулланыла алмый торганнарга бүленәләр.* Г.Шәйхиева. *Шулай ук әйбер яки эш-хәрәкәт һәм билгенең билгесен белдерүче сүзләр (сыйфатлар һәм рәвешләр) дә шактый, алмашлыклар һәм ярдәмлек сүзләр дә бар.* Р.Мөхиярова

**ЯРДӘМЛЕЛЕК** *и. к.* **ярдәмчеллек**

**ЯРДӘМСЕЗ** *с.* **1.** 1) Ярдәмгә мохтаҗ. *Томан арасында адашып туктап калган ярдәмсез пароходларның зарланган төсле сузып-сузып кычкыртулары җанны әрнетә, күңелне елыйсы килә торган тойгы белән каплый.* Гали Рәхим. *Бигрәк ярдәмсез иде шул мәрхүм.* Р.Батулла

2) Ярдәм итәргә яратмый, булышмый торган, ярдәм кулы сузмый торган. *Ул җитез, төпле комсомол җитәкчесе түгел, ярдәмсез тип булып гәүдәләнде.* М.Җәлил

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Үзе ярдәм кабул итмичә; мөстәкыйль рәвештә. *Бер дә ярдәмсез укый алмас.* З.Зәйнуллин. *Биш айлыкта инде ул һич ярдәмсез аяк атлый иде.* Ф.Яхин

2) Кешегә ярдәм күрсәтмичә. *Каткыннар чыга калсалар, курыкмаска, иптәшеңне ярдәмсез ташламаска, бер генә бодайны да дошманга бирмәскә.* А.Гыйләҗев

3) Чарасыз, көчсез хәлдә. *Чөнки көндез тәрәзәдән тышкы яктагы мәхшәрне өлешчә күрү мөмкинлеге булса, төнлә үзеңне бөтенләй ярдәмсез хис итәсең.* Ф.Хуҗин

**ЯРДӘМСЕЗЛЕК** *и.* Ярдәм булмау хәле. *Минем өчен төште артык кыйммәткә Ярдәмсезлек, кадерсезлек бәһасе.* Ф.Гыйззәтуллина. *Әтине озату миңа да, Галигә дә бераз моңсу булды, үзебездә ялгызлык, ярдәмсезлек тойдык, шулай да бераз күтәренкелек хисләребез дә бар иде.* Л.-Х.Таналин

**ЯРДӘМЧЕ** *и.* **1.** 1) Кемгә дә булса ярдәм итә, булыша торган кеше. *«Шайтан кала» дигән риваятьтә дә елан болгарларның ярдәмчесе һәм киңәшчесе итеп сурәтләнә.* А.Тимергалин. *Бу нәселне безнең яклардан бик еракта – Шотландия дигән илдә сарыклар көтү өчен көтүчеләргә ышанычлы ярдәмчеләр итеп чыгарганнар.* А.Хәсәнов // Хезмәтче. *– Иң матур шәлне китерегез аңа, – дип боера ярдәмчеләренә.* А.Нәҗми

2) Җаваплы урындагы кешенең рәсми, штаттагы булышчысы; урынбасар; ассистент. *Дружинин – комсомол эше буенча политбүлек начальнигы ярдәмчесе.* А.Алиш. *Врач ярдәмчесе, алгы бүлмәгә чыгып, тышкы ишеккә якынрак утырды ---.* Г.Әпсәләмов

**2.** *с. мәгъ.* 1) Ярдәм итә торган. *Кизүдәге шәфкать туташларыннан һәм табибтан башка аңа ярдәмче робот та беркетелде.* А.Тимергалин

2) Өстәмә, икенчел, төп функцияне башкармаган. *Инде ике тапкыр янгын да булып алды – хәзергә ул хәтле зыянлы түгел, ярдәмче сарайлар гына янды.* Г.Әпсәләмов. *Арырак байның ашлык амбарлары, аннан да арырак, икенче якта ат абзарлары, эреле-ваклы ярдәмче биналар булган ---.* Г.Госман

3) *лингв.* Үзенең мөстәкыйль мәгънәсе булмаган. *Шулай ук теләсә нинди фигыль ярдәмче фигыль ярдәмендә кушма (тезмә) фигыль ясый алмый.* И.Бәширова. *Ярдәмче сүзләр, мөстәкыйль мәгънәле сүзләр белән килеп, бер җөмлә кисәге була алалар (бәйлек һәм бәйлек сүзләр) яисә, җөмлә кисәге составына кермичә, җөмләләрне бәйлиләр (теркәгеч).* Татар лексикологиясе

**ЯРДӘМЧЕЛ** *с.* Ярдәм итүчән, ярдәм итәргә әзер булган. *Туганлык ул изге күңелле, ярдәмчел булуда икән...* А.Хәлим. *Бүтәннәргә аның кебек эшчән, ярдәмчел булырга ай-яй әле*! А.Әхмәтгалиева

**ЯРДӘМЧЕЛЛЕК** *и.* Ярдәмчел булу сыйфаты. *Ә онытылмый бит менә: кешелеклелеге белән, ярдәмчеллеге белән һаман күңелдә тора.* В.Нуруллин. *Ничәмә еллар инде Сәлимгәрәев монда балалар укыта, үзенең сабыр холкы, эшчәнлеге, ярдәмчеллеге белән абруй казанды, халыкның күңелен яулады.* З.Зәйнуллин

**ЯРДӘМЧЕСЕЗ** *с.* **1.** Ярдәмчесе, булышчысы булмаган. *Шушы бер гөнаһсыз, ярдәмчесез кызны үзеңә сыендыра алмыйсыңмыни соң?* З.Хөснияр

**2.** *рәв. мәгъ.* Ярдәмчедән башка, мөстәкыйль рәвештә. *Бабасы үлгәннән соң, Патый кулына эләккәч, тугыз яшьлек Таҗи бөтенләй ярдәмчесез калды.* М.Галәү. *Әле бит, поездларга утырасы, тәбәнәк платформаларга ярдәмчесез төшәсе, автобус йөрмәгән дала юлы буйлап мотоцикл арбасында кайтасы...* Р.Рахман

**ЯРЕН** *и. диал.* Киләсе ел. *Ярен әйтмә, борын әйт ---.* Дастан. *Кичәкөнлек бу тараф, кичә-көнлек бу тараф җирләрдә, чын кышлак кормыйча, башкортлар (истоклор) ыругы гына быел монда, ярен анда җәйләп-кышлап йөри.* Х.Сарьян

**ЯРЕНГӘ** *рәв. диал.* Киләсе елга. *Ярeнгә театр институтына китәм!* И.Юзеев. *Су буена сипсәң каурыйларын, Яренгә дә уңар казыгыз. Кызларыгыз очар чаклар җитте, Сагынырсыз, карап калыгыз!* Р.Миңнуллин

**ЯР ҖИМЕШЕ** *и. зоол.* Батманчыкчалар семьялыгыннан үгез башын хәтерләткән чикләвек бирә торган берьеллык су үсемлеге; су чикләвеге, батманчык; *русчасы:* **рогульник**

**ЯРКА** I *и. рус диал.* 1) Теше бәрән, саулык. *Карбюратор белән инжекторның аермасын сарык белән ярка аермасы дәрәҗәсендә дә күз алдына китермәгән Заһит бүтән дәшмәде.* Ж.Юныс. *Өч бәраннең икесе ярка, берсе кучкар*

2) Бәрәнләмәгән бер яшьлек сарык яки кәҗә. *Имеш, бер утыруда ярка билдәмәсен сыпыртып куя икән ул.* С.Лашманчы

**ЯРКА** II *и.* **1.** 1) Урталай ярылган утын агачы, түмәрнең бер яртысы. *Мин элек, Герман сугышына кадәрле, типсәм – тимер өзәрлек, кып-кызыл, нарат яркасы шикелле янып торган бер җегет идем ---.* Г.Камал. *Утын яркаларына ияреп кергән кар кисәкләре, кайнар чәйдә эрегән шикәр шакмаклары-дай, теләр-теләмәс кенә, агач пүләненә сеңеп юкка чыгалар.* Д.Булатова

2) Гомумән нәрсәнең дә булса эре ярылган бер кисәге. *Ниһаять, хлеборезкадан икмәк яркаларын китерделәр ---.* А.Гыйләҗев. *Канифә тизрәк сикереп торды, өстәл өстендәге җамаяктан инде суынып беткән ике-өч бәрәңге яркасы эләктереп, --- урамга атылды.* Н.Көбәш

**2.** *с. мәгъ.* Яртыга бүленгән, ярылган. *Табында күбрәк ярмалы ярка бәрәңге иде.* Ә.Салах

◊ **Ярка кебек** Нык, таза, тулы гәүдәле (кеше тур.). *Атаң шундый ярка кебек үсеп җиткән улы барлыкны күрсә нишләмәсие.* Г.Ахунов

**ЯРКА** III *с.* Иләнмәгән. *Ягасы ярка ямау тун ---.* Дастан

**ЯРКА́ДАЙ** *рәв. диал.* к. **ярка кебек**. *Ярлы кызы яркадай, ике күзе чаркадай.* Җыр. *Иван Степанович озын буйлы, имән яркасыдай таза кеше иде, да-а-а.* Т.Мөбарәков

**ЯРКАНАТ** *и. зоол.* Кулканатлылар отрядыннан киң яры канатлы, төнлә оча торган имезүче хайван. *Ни өчен ярканат яктыда очмый?* Г.Гыйльманов. *Мәче, бүре, ябалак, ярканат кебек төнлә ауга йөрүче җәнлекләр караңгылыкны мактый икән.* З.Мурсиев

**Я́Р КАРЛЫГАЧЫ** *и. зоол. к.* **керәшә**. *Кап-кара яр карлыгачы ипи кисәген эләктереп үк очып китте.* Р.Бәшәр

**ЯРЛЫ** *с.* **1.** 1) Матди мөмкинлекләре җитәрлек булмаган, фәкыйрь; *киресе:* **бай**. *Хафиз – авылның егетләреннән, ярлы кеше баласы.* Г.Камал. *Бай да, ярлы да түгел иделәр ---.* А.Нәҗми

2) Яшәү өчен кирәкле бар әйбере дә булып бетмәгән, җиһазландырылмаган, житешсез. *– Безнең ярлы йортымызга аяк баскан өчен, Аллаһы Тәгалә хәзрәтләре алтын-көмештән сарайлар бирсен! – дия иде.* Г.Исхакый. *Һәм... башланган җырын җырлап бетерә алмыйча, кинәт туктап калды: ул бүген беренче мәртәбә үзенең шыксыз, буш һәм ярлы фатирына игътибар итте.* Г.Гыйльманов // Зиннәтсез, үтә гади. *Иң элек чалмасы, таягы, ярлы туны, таракан ашаган читеге белән Фәйзулла мөәззин килде.* Г.Ибраһимов

3) Ярлылар яшәгән, ярлыларны-ку булган; фәкыйрьлек хөкем сөргән. *Алар шәһәрнең читендә иң сәләмә, иң ярлы мәхәлләдә тора иделәр.* Ш.Камал. *Бары шәһәрнең иске һәм ярлы районнарында бит-күзен каплаган хатыннар күренгәли.* М.Госманов

4) Бик аз, бик арзан әйберләрдән торган. *Табын шулкадәр ярлы, арык иде ки, ашап тамак та, карап күз дә туярлык түгел иде.* А.Гыйләҗев

5) Мохтаҗлык кичерелгән; яңгырсыз һәм уңышсыз. *Еллар ярлы, җиде баланың тамагын туйдырып, өс-башын карап тору җиңел түгел.* Г.Галиева

6) Составында кирәкле, файдалы матдәләр, минераль тозлар җитәрлек булмаган; уңдырышлылыгы түбән булган. *Аурупага килгәч, гуннар 200 елга якын шактый ярлы туфраклы далада яшиләр һәм күршедәге бер халык белән дә сугышмыйлар.* М.Хәбибуллин. *Кислородка ярлы туфракта үсә торган үсемлекләр (мәсәлән, тропик мангр агачы) сулыш тамырлары барлыкка китерә.* Биология

7) Аз булган, төрлелек күзәтелмәгән. *Дару үләннәрен өйрәнүгә килсәк, Тибетта үсемлек дөньясы гаять ярлы булып чыкты.* З.Мурсиев

8) *күч.* Эшләнеп җитмәгән; эчтәлеге бай булмаган, сәнгатьчәлеге түбән дәрәҗәдәге. *Теле шулай ярлы булганмы аның?* А.Гыйләҗев. *Һәм, киресенчә, сюжеты ярлы әсәр, язучының бер урында таптануы укучы өчен ялыктыргыч, эчпошыргыч булып китәргә мөмкин.* К.Гыйззәтов

9) *күч.* Кызыгы булмаган, төссез, нурсыз, шыксыз. *Әгәр Мөнирә булмаса, аның тормышы никадәр нурсыз, төссез, ярлы булыр иде!* Г.Әпсәләмов

**2.** *рәв. мәгъ.* Фәкыйрьлек, хәерчелек белән, фәкыйрь тормыш белән, матди мохтаҗлык күреп. *Мин – ярлы торырга өйрәнгән кеше.* Г.Ибраһимов. *Колхозыбыз ярлы гына яши шулай ---.* Г.Афзал

**3.** *и. мәгъ.* 1) Яшәү өчен матди мөмкинлекләре җитәрлек булмаган фәкыйрь кеше. *Бай колагы ярлы сүзен ишетми икән шул.* В.Имамов. *Байның саранлыгы, ярлының юмартлыгы – икесе бердәй бәла.* М.Галиев

2) **ярлылар** *күпл. тар.* Тоташ коллективлашуга кадәр, кулаклар һәм урта хәллеләрдән аерым буларак, иң фәкыйрь крестьяннарны эченә алган социаль катлау. *Ярлылар комитеты дилбегәне кулында нык тота икән.* В.Нуруллин. *Менә шул камисар хәзер бөтен кантун буйлап ярлылар ширкәте эшен яңартуны бездән таләп итә.* В.Имамов

**ЯРЛЫК** *и.* 1) *тар.* Хан боерыгы, фәрман, язма указ. *Ярлыклар икесе дә хан исеме белән башлана һәм ярлык ияләренең нәсел вәкилләре ия булган өстенлекләрне раслый.* Б.Хәмидуллин // Хан, кенәз һ.б. булу хокукы бирә торган, дәүләт башлыгы тарафыннан бирелгән рәсми таныклык. *Менә шуны үлчәп, Габдулла хан олуг кенәз ярлыгын яшь кенәзгә язып биргән иде.* В.Имамов

2) Әйбернең атамасы, бәясе һ.б.ш. мәгълүмат язылып ябыштырылган яки эленгән кәгазь; этикетка. *Сатып алган алтын әйбердә ярлык – квадрат рәвешендә яки озынчарак кәгазь кисәге булырга тиеш.* Өмет. *Маркировка эшләнмәнең үзенә яки аңа беркетелгән этикеткага, товар ярлыгына, төргәгенә яисә язулы кәгазьгә салына.* Маяк

3) Шаблон характердагы кушамат; шәхеснең дәрәҗәсен, абруен төшерә, тискәре бәяли торган сыйфатлама. *Бер ярлык тагылгач, һәр адым бизмәнгә салына.* З.Мәхмүди

**ЯРЛЫКАТУ** *ф. йөкл. юн. к.* **ярлыкау**. *Яшәүнең Алла хөкеме икәнен, гөнаһларыбызны ярлыкатыр өчен Хаҗга килүебезне онытмыйк.* Ә.Зарипов

**ЯРЛЫКА́У** I *ф.* 1) *дини* Гафу итү, кичерү (гадәттә, гөнаһларны). *Ә менә аларның бүген кич кылыначак гөнаһ гамәлләрен кайчан да булса ярлыкый алырсыңмы соң?..* З.Хөсния. *Кыскасы, Төхбәтулланың хатынына кул күтәрүен Тәңребез ярлыкамады шикелле.* З.Мурсиев

2) Аяу, җәзасыз калдыру. *Үлемгә хөкем ителгәнне ярлыкау*

**Ярлыкап тору** Һәрвакыт, гел ярлыкау. *Мин боларны, бу дөньяда барлык гөнаһларны ярлыкап торырга кирәк, дигәннән әйтмим, аерым хәлләрдә кичерә дә белү ярый, дип сөйлим.* Б.Камалов

**ЯРЛЫКА́У** II *и.* 1) *дини* Гафу итү, кичерү эше. *Мәккәдә ачты бүген якты иманга баб Ходай, ярлыкау эстә, шөкер ит, тәүбә кыл, тәүваб Ходай!* Г.Тукай. *Зарны кирәк җанда яткырмау: Салып куй да, ерак бабаң өчен Тәүбә китер, сора ярлыкау!..* И.Гыйләҗев

2) *юр.* Үлем җәзасына хөкем ителгән җинаятьченең хөкемен үзгәртү

**ЯРЛЫЛАНДЫРГЫЧ** *и.* **1.** *махс.* Шлак, кушылма һ.б.ш.дан ниндидер матдәләрне аеру, бүлеп чыгару өчен, технологик процесс барышында өстәлә торган матдә; *русчасы:* **обеднитель**. *Ул саф килеш яисә ярлыландыргычлар, күзәнәк ясагычлар, эреткечләр, пластификаторлар һ.б. өстәп кулланыла.* Төзү материаллары

**2.** *с. мәгъ* Ярлыландыра торган; ярлыландыру (*3 мәгъ.*) өчен кулланылган. *Вату һәм төюдән соң калган керамик ватык-китекне керамика җитештергәндә ярлыландыргыч өстәлмәләр, бетон һәм измәләргә тутыргыч итеп файдаланырга мөмкин.* Төзү материаллары

**ЯРЛЫЛАНДЫРУ** *ф.* 1) Ярлы итү, бөлгенлеккә, фәкыйрьлеккә төшерү. *Дөнья бутый, илне ярлыландыра, кешене эт көненә калдыра торган бер зәкъкум бар, ул да булса – аракы, имеш.* С.Поварисов

2) Составындагы кирәкле матдәләрне, минераль тозларны киметү (азыкның, туфракның һ.б.). *Бу хәл җирне әкренләп ярлыландыра.* Дөнья кисәкләре географиясе. *Шулай ук амброзия туфракны ярлыландыра, уңыш бирүне кискен киметә икән.* Кәеф ничек?

3) *хим.* Берәр масса, кушылманы махсус эшкәртеп, андагы кирәкле матдәләрне аерып алу

4) *күч.* Эчтәлеген саектыру, образлылыгын, матурлыгын, төзеклеген, тәэсирен киметү (сәнгать әсәре, тел һ.б.ш. тур.). *Ләкин ни өчен без поэзиябезне белә торып ярлыландырырга тиеш?* М.Шабаев. *Логика сүзе, термин буларак, татар телендә дә нигез ташы булып торырга тиеш, югыйсә без фән телебезне гадәттән тыш ярлыландырачакбыз гына, ягъни киләчәктә үзебезгә үзебез комачау тудырачакбыз.* А.Тимергалин

**Ярлыландыра бару** Торган саен ярлыландыру. *Бер караганда башка сыйдыра алмаслык хәл: нефть акчалары ташкыны ярлыларны тагын да ярлыландыра бара.* Ф.Зариф

**Ярлыландыра төшү** Тагын да ярлыландыру. *«Әгәр минималь куллану кәрзинен баету чарасы күрелмәсә, ул ярлыларны тагын да ярлыландыра төшәчәк», – дигән нәтиҗә ясый профсоюзлар лидеры ---.* Ватаным Татарстан

**Ярлыландырып калдыру** Ахырда ярлыланган хәлгә китерү. *Заман героен тасвирлаганда, авторлар гүяки аны тышкы дөнья белән бәйли торган җепләрне юри өзәләр, ә болай аерып кую геройның эчке дөньясын ярлыландырып калдыра.* Р.Мостафин

**ЯРЛЫЛАНУ** *ф.* 1) Бөлү, фәкыйрьләнү. *Бик ярлыланды безнең халык.* А.Тимергалин. *Авылда сырхаулар күбәйгән, халык ярлыланган, бөлгән.* Г.Гыйльманов

2) Составындагы кирәкле матдәләр, минераль тозлар кимү (азык, туфрак һ.б. тур.). *Аның да хәлләре мөшкел иде: уңдырышы – гумусы – елдан-ел кими барды, туфрагы ярлыланды.* И.Усманов

3) *күч.* Эчтәлеге саегу, образлылыгы, тәэсир көче кимү (әсәр һ.б. тур.). *Бу хикәяләрне рус теленә тәрҗемәләре белән чагыштырып карагач, шул да аңлашылды: русча текст шактый ярлыланган, кыскарган, автор стиленә хас милли үзенчәлекләр төссезләнеп югалып калган, йоннары-төкләре коелган иде.* Р.Даутов

4) *күч.* Мораль, этик һ.б.ш уңай сыйфатлары кимү, юкка чыгу. *Табигать шәрәләнеп калгач, адәмнәрнең җаны ярлыланды, тупасланды, мәхәббәтләре сүрәнләнде, туган җирләреннән суынды.* И.Юзеев. *Әгәр кеше үзенең хәтерен үткәндәге истәлекләре белән яңартып тормаса, аның хәтер чишмәсе саега, һәм бу кеше рухи яктан ярлылана.* Ф.Яруллин

5) *күч.* Тулылык, бөтенлек күзәтелмәү, үсеш-үзгәреш биргән нәрсә бетү, юкка чыгу. *Әгәр дә ул озын, бормалы-бормалы җырларыбыз онытылса, юкка чыкса, татар халкының җыр мирасы бик нык ярлыланыр иде.* Р.Вәлиев. *Андый шәхесләр булмаса, тарихыбыз күпкә ярлыланыр иде.* Ф.Хуҗин

**Ярлылана бару** Торган саен ярлылану. *Урманнар киселә, сулыклар, һава пычрана, туган як табигате елдан-ел ярлылана бара.* А.Хәсәнов. *Көндәлек тормышның кырыслыгы алгы планга чыкты, шуңа күрәдерме, сурәтләү чаралары көннән-көн ярлылана бара.* К.Кәримов

**Ярлылана башлау** Ярлылану билгеләре сиземләнү. *Шуннан синең гонорардан килгән акча белән калынайган бай кесәң ярлылана башлый.* С.Поварисов. *Әдәбиятка игътибар итмәү нәтиҗәсендә безнең телебез дә ярлылана башлады.* Кызыл таң

**Ярлылана төшү** Бераз ярлылану; тагын да ярлылану. *--- труппадагы артистларның берничәсе солдатка алынгач (Ш.Шамильский һ.б.), «Нур» труппасының составы ярлылана төшә.* Х.Гобәйдуллин

**Ярлыланып бару** Торган саен ныграк ярлылану. *Мондый шартларда туфракның елдан-ел ярлыланып баруы көн кебек ачык.* Ютазы таңы

**Ярлыланып бетү** Тәмам ярлылану. *Шул ярлыланып бетеп, авылдан өмет өзеп, үзенең эшләп йөргән җиренә – агач заводына бөтенләй күчеп китте.* Г.Ибраһимов

**Ярлыланып калу** Берәр сәбәптән ярлыланган хәлгә килү. *Кеше хисләренең бик ярлыланып калган чакларын беләм.* С.Хәким. *Кешеләр дисең, үз күңеле дә дөньяга шыплап ябылган, күз карашлары да төсләргә ярлыланып калган, табигый нурларын җуйган...* Г.Гыйльманов

**Ярлыланып китү** Кинәт ярлылану. *Бичура бар чагында бай гына торган кешеләр, яхшы Бичура китсә, бөтенләй ярлыланып китәләр икән.* Әкият

**ЯРЛЫЛА́РЧА** *рәв.* **1.** Ярлылар кебек. *Ярлыларча яшәү*

**2.** *с. мәгъ.* Ярлыларныкы кебек булган. *Бай угылы Закир, бай кызы Гөлбану һәм бай хатыны Сабира – өчесе дә ярлыларча тормышка мәхкүм иде.* Г.Ибраһимов

**ЯРЛЫЛЫК** *и.* 1) Фәкыйрьлек, бөлгенлек, матди яктан бик авыр хәл. *Һиндстанда бөтен гомерен ярлылыкта, хәсрәттә кичергән бер Балыкчы карт бар иде.* Г.Тукай. *Ходай бит ничек дигән: ярлылыкта да, байлыкта да, шатлыкта да, кайгыда да бер-береңне ташламаска, бергә булырга, дигән.* З.Кадыйрова

2) Составында кирәкле матдәләрнең, минераль тозларның җитәрлек булмавы (азык, туфрак һ.б.ш. тур.). *Азыкның ярлылыгы*

3) *күч.* Түбән дәрәҗәдә, начар булу, эшләнеп бетмәү күренеше; җитлекмәгәнлек. *Боларда җансызлык, ярлылык, корылык һәм образсызлык күзгә ташлана.* М.Җәлил. *Ягъни ул телнең байлыгы турында түгел, бәлки ярлылыгы, җитлекмәгәнлегe, мескенлеге турында сөйли башлый.* А.Тимергалин. *Иҗади күтәрелештән соң иҗади ярлылык, түбән төшү дә сәнгать тарихына ят нәрсә түгел.* Р.Батулла

◊ **Ярлылыкка төшү** Ярлылану, бөлү. *Элеккедән калган мал беткән, хәзер ярлылыкка төшкәннәр.* Г.Ибраһимов. **Ярлылыкка чыгу** *к.* **ярлылыкка**

**төшү**. *Чура Шагали хан янында урысларга каршы сугышып йөргән арада, Гали бинең якыннары, яңадан килеп, Нарәңнең йорт-курасын талап киткәннәр, Нарәң үзе ярлылыкка чыккан икән.* Дөнья цивилизациясендә татар дастаннары

**ЯРЛЫ́-ЯБАГА(Й)** *җый. и.* Ярлы халык, фәкыйрь-фөкара. *Икмәкне байлардан алганнар да ярлы-ябагайларга чәчүлек орлык биреп торганнар, кала эшчеләренә озатканнар, пычакка-пычак килгәннәр...* А.Гыйләҗев. *Зөлфиям саусәламәт кайтса, гел изге юлда йөреп, ярлы-ябагага ярдәм итеп, явызлыкка каршы көрәшер идем.* Т.Галиуллин

**ЯРМА** *и.* **1.** Кайбер үсемлекләрнең кабыгыннан чистартып бөтен яки вакланган хәлдә ризык буларак кулланыла торган орлыгы. *Бәдри абзыйның амбарлары тулы ит, ярма, богдай, арышларны күргәч, мин аны бу авылның иң бай кешеләреннән берсе икәненә хөкем иттем.* Г.Тукай. *Көненә бер мәртәбә бер уч арыш ярмасыннан пешерелгән аш эләгә.* В.Нуруллин

**2.** *с. мәгъ.* Вак кына бөртекләрдән торган һәм каты (кар тур.); *русчасы:* **крупа**. *Каршы яктан искән җил, аларның бишмәт чабуларыннан сөйрәп, авылга таба тарткаладады, итек куныычларына, куеннарына учы-учы белән ярма кар тутырды.* А.Гыйләҗев. *Яңгыр ява минем тәрәзәмә, Синең тәрәзәңә – ярма кар. Урталайга ярган алма кебек Аеры үтә безнең язмышлар!* С.Гәрәева

◊ **Ярма бөртеге кадәр** Аз, бик аз гына. *Таланган күңелдә ярма бөртеге кадәр генә булса да өмет бар!* А.Гыйләҗев. **Ярма бөртеге кадәр дә** Бер дә; һич тә. *Февраль башлары җиткәндә инде ул тамагына ярма бөртеге кадәр дә азык каба алмый иде.* Г.Рәхим. **Ярма яру** Ялган сөйләү; арттырып, күпертеп сөйләү. *Соңгы көннәрдә, Гитлерны чәнчелдерергә секретный приказ алып Берлинга очканда, аэропланымны бәрделәр, егылып, аягым сынды, дип ярма яра башлаган [Хөсәен абзый].* Г.Мөхәммәтшин. – *Уф Аллам, яра бит ярманы ярпач, синең кебек тел бистәсе белән кем тора алсын соң!.. – диде [апа].* М.Хәбибуллин

**ЯРМА́-ОН** *җый. и.* Төрле ярма һәм он кебек ашлык. *Билгеле инде, икесенең дә келәтләрендә капчык-капчык борчак, ясмык, ярма-он, комбиазык утыра.* А.Хәсәнов

**ЯРМАЛАНУ** *ф.* 1) Бөртекле культураларның орлыгын ваклау яки кабыгыннан арындыру нәтиҗәсендә ярма рәвешенә килү, ярма булу, ярмага әйләнү. *Тары бөртекләре ярмалану*

2) Кисәкләргә аерылып, таралып тору; укмашмыйча бөртекләнеп тору. *Көндез бераз җепшетеп алган аяк асты ярмаланып каткан иде.* Л.Ихсанова. *[Солтангали абзый] Гадәтенчә башкорт бәрәңгесен – аның эрелеген, ярмаланып тәмле булып пешүен мактап ала.* Г.Госман

**Ярмаланып бетү** Тәмам, бөтенләй ярмалану. *Бәрәңге пешкәч, бөтенесе җыелып, ярмаланып беткән тәмле бәрәңге ашыйлар.* Идел

**Ярмаланып китү** Бераз, берникадәр ярмалану. *Җир ананың куенында тагы да үсеп, ярмаланып киткән йодрыктай бәрәңгеләрен, киптереп, базларына салып куйдылар.* Р.Сафин

**Ярмаланып тору** Әле, күз алдында ярмаланган хәлдә булу. *Туфрагын ипигә ягып ашамалы, гөл балчыгы төсле ярмаланып тора.* Ф.Садриев. *Аннары мин әле яшькелт сары чәчәкләре ярмаланып торган миләшкә карап тордым.* Т.Нурмөхәммәтов

**ЯРМАЛЫ** *с.* 1) Ярма салынган, ярма тутырылган. *Малайлар, сөтле чиләкләрен, майлы табакларын, ярмалы капчыкларын күтәреп, читәннәрне кыйный-кыйный, урам буйлап киттеләр.* И.Гази

2) Ярма салып пешерелгән. *Тары үсә, кыр тутырып, сибенке баш – Булыр безгә кыш көнендә ярмалы аш.* В.Ильясов. *Нәүрүз көнне безнең дә Кояшка сый итеп әзерләгән җиде [төрле] ярмалы майлы боткабыз бар иде, аны, елдагыча бик тәмле итеп, Әминә ханым Хисмәтуллина зур бер казан белән пешереп китерде.* Бөтендөнья татар конгрессы

3) Ярма кебек бөртекләнеп, таралып торган. *Кушучыңа алып ашардай ярмалы кара балчыгына хәтле газиз иде шул.* Р.Кәрами. *Ярмалы алма бераз әчкелтем дә, татлы да иде.* Сөембикә

**ЯРМИНКӘ** *и. нем.* Елның бер үк вакытында һәм билгеле бер урында ел саен үткәрелә торган зур сәүдә базары. *Казан ханлыгы заманында Үкәк каласында ярминкә буладыр икән.* К.Насыйри

**ЯРМИНКӘЛЕ** *с.* Ярминкә оештырылган. *Әмәкәй заманында волость үзәге, базарлы, ярминкәле зур авыл булган.* Безнең мирас

**ЯРОВИЗА́ТОР** *и. рус а.х.* Яровойлаштыру белгече

**ЯРОВОЙЛАШТЫРУ** *ф. а.х.* 1) Язгы чәчү алдыннан авыл хуҗалыгы культураларының шытуын, үсеш-өлгерешен тизләтү максаты белән, чәчүлек орлыкны түбән температурада тоту. *Орлык бәрәңгесен никадәр озаграк яровойлаштырасың, ул авыруларга каршы шуның кадәр ныграк тора.* Шәһри Казан

2) Аерым культураларны яз көне чәчә торган культурага әйләндерү. *Без бакчачы карт Мичуринны, яровойлаштыру белән шөгыльләнгән Лысенконы гына белә идек.* Казан утлары

**Яровойлаштыра башлау** Яровойлаштырырга керешү. *Хәзер орлык агулау, бәрәңге яровойлаштыра башлау өчен әйбәт вакыт.* И.Фәттахов. *Кәбестә орлыкларын чәчүгә 17–22 көн, петрушка һәм суганны 15–20 көн калгач яровойлаштыра башлыйлар.* Йорт эшләре

**ЯРОВОЙЛАШУ** *ф.* 1) Урта климат үсемлекләренең көннәр суыта башлауга җавап реакциясе буларак физиологиясе үзгәрү

2) *а.х.* Яровойлаштырылган булу. *Кайбер үсемлекләр бөтенләй ботакланмыйлар, алар яровойлашу стадиясен үтмәгән булалар.* Биология

**ЯРПАЧ** *с. диал.* Шапырынчык, мактанырга яратучан, мактанчык. *Уф Аллам, яра бит ярманы ярпач.* М.Хәбибуллин

**ЯРПАЧЛАНУ** *ф. диал.* Шапырыну, мактану. *Ул башта, ярпачлана гына бу егет, дип уйлаган иде, ышанмаган иде.* М.Әмирханов. *Шул үй белән кыргычны тиз генә күтәрергә дип ярпачланган егет берничә әйләнештән үк тирләп чыкты.* Казан утлары

**ЯРПАЮ** I *ф. диал.* 1) Шапырыну, мактану

2) Эреләнү, тәкәбберләнү, үзен тәкәббер, бик эре тоту. – *Син ничәнче елгы? – дип сорагач, ул дөресен әйтмәде, ярпаеп, үзен өч яшькә олы итеп күрсәтте.* Р.Кәрами

**ЯРПАЮ** II *ф. диал.* Яхшыру, уңайлану, әйбәтләнү. *Яңгыр ява, җир дымая, Яшь үләннәр ярпая.* Җыр. *Яхшыга ияргән ярпайган, яманга ияргән картайган.* Мәкаль

**Я́Р ПЕСНӘГЕ** *и. зоол.* Песнәкчәләр семьялыгыннан соры башлы, кара маскалы, кызгылт көрән аркалы, елга-күл буйларында яшәүче кош; *русчасы:* **ремез**

**ЯРСУ** I *ф.* 1) Берәр тышкы тәэсиргә реакция күрсәтү, киерелү

2) Ачу кабарудан соң чиккә җитеп кызып китү, шашыну, җикеренү. *Мин, ярсып, йодрыкларымны йомарлап аларга ташлана, этиемне яклый идем.* А.Гыйләҗев. – *Кайтуга ук, мин Хаҗитархан өстенә зур яу белән чабам, аны үземнең олысыма әйләндермичә тукталачак түгел! – дип ярсыды Мөхәммәдгәрәй, тезгенен үз көенә селкеп.* В.Имамов

3) *Күңел, йөрәк* сүзләре белән килеп: тынгысызлану, гасабилану, ни эшләргә белмәү, рухи газаплану. *Аның йөрәге тагын ярсыды, җаны сызылды. Иң кадерле кешеләре тау эчендә бикләнеп калган бит: ничек борчылмыйсың да, ничек өзгәләнмисең ди.* Г.Гыйльманов

4) Көчле дәрт, теләк белән ашкыну, нәрсә дә булса эшләргә җилкенү, туктаусыз омтылу; алгысу. *Халык үзен ерылган буа сыман тотты: шаулашты, талпынды, ярсыды, гүя ачудан нәрсәнедер җимерергә ашкына иде.* З.Мурсиев

5) Ажгырып тору, котырып чабарга әзер булу. *Кызып ярсыган атларны [таудан] тыеп кына төшмәсәң, әллә нинди бәлаләр китереп чыгарулары бар.* Н.Әхмәдиев. *Бер тибүдә арангулакларны ярырдай булып ярсыды ул [Акъял].* В.Имамов

6) *күч.* Көчле ташкын булып агу. *Чишмә суы ярсып агуыннан туктады, тыйнак, салмак кына йөгерергә кереште.* Г.Гыйльманов. *Мәргуәнең шуннан соңгы тормышы гранит ярлар арасыннан ярсып аккан тау елгасыныкына охшаган.* Сөембикә

**Ярсый башлау** Ярсырга тотыну. *Чабыш атлары Сабантуй якынлашу белән ярсый башлый, дип сөйлиләр.* Ә.Моталлапов

**Ярсый төшү** Тагын да ныграк ярсу. *Хурлыгыннан тагын да ярсый төште.* А.Хәсәнов

**Ярсып бетү** Тәмам, бик нык ярсу. *Әнисе аны кочагына алды, бәллүкиләп юатырга кереште, ләкин бала һаман туктыйсы итмәде, үкси-үкси ярсып бетте.* А.Тимергалин

**Ярсып кую** Кинәт ярсу. *Кайчакларны көчле яңгырлардан соң, ярларыннан чыгып ярсып куйса, мин сиңа әйтим, киң Иделгә тиң була.* А.Хәсәнов

**ЯРСУ** II *с.* **1.** 1) Ярсыганы беленеп торган, ярсулы. *Күзләренең агын әйләндереп, ярсу ачу белән Симайга карап алды ул.* Ш.Маннур. *Яугирләрнең ярсу авазыннан кошлар куркып һавага күтәрелде, җәнлекләр ояларына постылар.* Р.Зәйдулла

2) Көчле агымлы, ташкынлы. *Ярсу елганың агышын күзәткән кеше белә булыр: дулкыннар гел агымга каршы йөгерә.* Р.Фәйзуллин. *Шаулап, гөрләп аккан киң сулы ярсу дәрьялар!* М.Вәлиев

3) Ашкынулы, дәртле, рухландыра торган. *Басуларга, болыннарга чыкканда күңелең сизеп тә, телең белән әйтеп бирә алмаган әнә шул ярсу тойгылар дәртле җыр булып җырланмадымы икән?* Г.Бәширов. *Күк зәңгәрлеге турында сер сөйләп, җирне сөендерүе, җир яшеллеге турында җыр көйләп, күкне шатландыруыдыр инде, күрәсең, ярсу йөрәкле кошның.* Ф.Шәфигуллин

**2.** *и. мәгъ.* Ярсулы халәт. *[Борисов] Ярсудан, ачудан үзеннән-үзе җиңеләеп, гәүдәсен туптай очындырып, бер солдатка кадады да артка сикерде.* Г.Бәширов. *Җитез җилдәй аны алга әйдәүче көч – йөрәктән ургылган тиле яшьлек ярсуы.* А.Вергазов

**ЯРСУЛЫ** *с.* 1) Ярсыган

2) Ярсуы кагылдырган, ярсуны белдергән. *Хәйдәр тирәсенә җыелышып баскан хатын-кызларның үзенә төбәлгән ярсулы карашын күргәч, Зөбәйдә, башын түбән иеп кенә, читкә атларга мәҗбүр булды.* В.Имамов

3) Газаплы, борчып торган, тынычлыгын алган. *Галиянең елмаюы йөрәгенең авырткан урыннарындагы ярсулы хисләрен алып ташлаган кебек булды.* Һ.Такташ

4) Көчле, куәтле, егәрле. *Диңгез шаулаганы, кайдадыр бәрелгән дулкынның ярсулы чупылдавы ишетелде.* Н.Акмал. *Елга солдатларны ачулы шаулап каршылады: ул ярсулы дулкыннарын ярга китереп бәргәндә, тирә-якка чәчрәгән тамчылар шыбырдап кире коелалар.* Әдипләр

**ЯРСУЧАН** *с.* Еш ярсый торган, тиз ярсып китүчән. *Ярсучан күңелен юатыр өченме икән, ул соңгы сулышына кадәр бөтен гомерен «чабышларда йөрәге ярылып үлә торган чабыш аты сыман» яши.* М.Гайнетдин

**ЯРСУЧАНЛЫК** *и.* Ярсучан булу сыйфаты. *Баланың агрессивлыгы артына кайчакта төрле авырулар да яшеренгән була, әйтик, нерв ярсучанлыгы.* Ватаным Татарстан

**ЯРСЫНУ** *ф.* 1) Нык ярсу. *[Җирән кашка] Очына, ярсына, арт аякларына басып кешни, җаным. «Һайт, Кашка!» – дип кычкырып җибәрүем булды – таныды, бахыр, минем якка борылды...* И.Юзеев

2) *мед.* Борчылу; тынычсызлану, хәвефләнү; тышкы ярсыткыч тәэсиренә бирелү. *Сулыш алуның тирәнлеге һәм ешлыгы организмның кислородка һәм углекислый газга булган ихтыяҗлары белән көйләнә. Бу көйләү механизмнарында углекислый газ белән ярсына торган хеморецепторлар катнаша.* Р.Гарифуллин

**Ярсына башлау** Ярсынырга тотыну

**Ярсынып китү** Кинәт ярсыну. – *Алдаша, андый эшнең гомердә дә булганы юк, ипидер әгәр, – дип ярсынып китә кухарка.* Г.Ахунов

**Ярсынып кую** Кинәт, кыска вакытка, аз гына ярсыну. *Бала гына әллә ыңгырашып, әллә ярсынып куйды.* Р.Гаязетдин

**Ярсынып тору** Һәрвакыт, гел ярсыну. *Яхшылыклар эшләргә күңеле ярсынып тора аның.* Ислам

**ЯРСЫТКЫЧ** *с.* **1.** 1) Ярсыта, киеренке хәлгә китерә, тынычсызлый торган. *Көньяк Африкада атналар буе дәвам иткән дини бәйрәмнәрдә җирле халык «доп» дип аталган ярсыткыч эчемлек куллана икән.* Татарстан яшьләре. *Банан ашказанын ярсыткыч матдәләрдән һәм ризыкта булган кислоталардан саклый, һәм бу – җәрәхәтнең төзәлүенә ярдәм итә.* Яшел Үзән

2) Җилкендергеч, ашкындыргыч, дәртләндергеч. *[Таң атканда әтәч тавышы] Йөрәк күзәнәкләренә әллә нинди ярсыткыч, җилкендергеч, шаштыргыч моң салып, сине бераз тилертеп ала, әллә нинди кайгы-хәсрәтсез якты дөньяга әйди, күңелеңне хозурлык биләве белән били.* С.Поварисов

**2.** *и. мәгъ. мед.* Ярсыта, борчый торган нәрсә. *Баланың баш миендәге сөйләм зоналарына гадәттәгедән көчлерәк ярсыткыч тәэсир иткәндә, сөйләм өзеклеге – тотлыгу барлыкка килә.* Кызыл таң

**3.** *рәв. мәгъ.* Ярсытырлык итеп, ярсу дәрәҗәсенә җиткереп. *Зур кибетләрдә, базарларда булу балага кирәгеннән артык ярсыткыч тәэсир итә.* Биектау хәбәрләре. *Аллергия чыганаклары күп төрле: хайваннарның йоны, тиресе, үсемлек серкәләре, урам, өйдәге тузан һәм еш кына ашаган ризык та кайвакыт кеше организмына ярсыткыч тәэсир ясый.* Мәйдан

**ЯРСЫТУ** *ф.* 1) Кешенең, үзен белештермәслек дәрәҗәгә җиткереп, ачуын чыгару, нык көчле ачуын китерү. *Нурия, үзен үзе ярсытып, Хәнифә*

*түтәй белән әрепләшеп озак ята. Тынычлана алмый аптырап бетә.* Г.Ахунов

2) Җилкендерү, ашкындыру, дулкынландыру. *Алсу чатырлы кәмә, күзнең явын алып, күңелләрне кытыклап, ярсытып, ашыкмыйча, су уртасына барды да барды.* Н.Фәттах. *Күңелләрне җилкетеп, йөрәкләрне ярсытып яз килгән чак иде.* М.Маликова

3) Тынычсызлау. *Пикадорларның максаты – үгезне беркадәр хәлсезләндереп һәм тагын да ярсытып, аны аренаның төп хуҗасы – матадорга әзерләү.* Р.Фәйзуллин. *Нерв күзәнәкләрен ярсыту*

4) Күңелне борчу

**Ярсыта бару** Торган саен ныграк ярсыту

**Ярсыта башлау** Ярсытырга тотыну. *Хәмбәл, алыш алдыннан тояклары белән җир чокыган гаярь үгез сыман, үзен үзе кыздыра, ярсыта башлады.* В.Имамов

**Ярсыта төшү** Тагын да ныграк ярсыту. *Авар дип көткән Шәех егылмады, бары тик чайкалып кына куйды, бәлки, Жбанны нәкъ менә шул тагын да ярсыта төшкәндер.* Ә.Мушинский

**Ярсытып алу** Аз гына, кыска вакыт арасында ярсыту. *Әти, футбол уйнаучы малайларны күрде исә, тукталып күзәтеп тора, җиңелә башлаганны ярсытып ала.* К.Гыйззәтов

**Ярсытып бетерү** Тәмам, бик нык ярсыту

**Ярсытып җибәрү** Кинәт ярсуга этәргеч бирү. *Нургалинең болай балаларча аңламаганга салынып утыруы Миңсылуны тагын ярсытып җибәрде.* Ә.Еники. *Тилмереп әйтелгән бу сүзләр сугышчыларның күңелен ярсытып җибәрде.* Г.Әпсәләмов

**Ярсытып куюю** Кинәт, кыска вакыт арасында ярсыту. *Юк, аны нindидер качкыннар кызыксындырмады, күңелен нәкъ менә Җик Мәргән җилкендереп, йөрәген ярсытып куйды.* М.Хәбибуллин

**Ярсытып тору** Һаман, бертуктаусыз ярсыту. *Исәнбикә болыны, Яманташ тирәсе урманнарындагы чыпчык башы зурлыгы пешкән кып-кызыл җиләкләр һәркемне яннарына чакырып, йөрәкне ярсытып торалар.* С.Поварисов. *Җитәр, тизрәк хәл итәргә кирәк, болай йөрәк ярсытып торуның мәгънәсе юк...* Г.Гыйльманов

**ЯРТЫ** *и.* **1.** 1) Бергәләп бербөтенне тәшкил итә торган тигез ике өлешнең берсе. *Алманың яртысы нәрсәгә охшаган? Җавабы – икенче яртысына.* Табышмак. *Читтә күргән үрнәк белән, ул Зәйтуганда беренче булып зур җимеш бакчасы булдырды, моның өчен бакчасының яртысын бүлеп алды.* Ф.Бәйрәмова

2) Озынлыкка, киңлеккә яки биеклеккә сузылган әйбернең уртасы. *Без инде, Иделнең яртысына җитеп, каршыбызга килгән буксир пароходның астына керми узарга тырыша идек.* Г.Рәхим. *Ибраһим инде Елантау итәгенең яртысына менеп җиткән иде.* В.Имамов

3) *гади с.* Бер шешә аракы. *Егетләр, эш беткәч алай да миңа бер ярты куярсыз.* А.Хәсәнов

4) *күч.* Нәрсәнең дә булса шактый зур, әһәмиятле өлеше. *Ярты дөньяны яулап алган патшалар да каршы тора алмаган үлемгә...* В.Нуруллин. *Ярты ханлыкны авызыңа караттың ла инде.* В.Имамов

**2.** *сан функ.* Исемнәр һәм вакыт, исәп-хисапны белдергән саннар белән килгәндә: бөтеннең икедән бере. *Бер бау криндел, манпаси, өч йөз грамм мәк хәлвәсе, ярты кило караҗимеш сатып алдылар.* А.Гыйләҗев. *Беркөнне дә уянып китсәм – сәгать сигезенче ярты булган.* В.Нуриев

**3.** *рәв. мәгъ. сөйл.* Яртылаш, өлешчә. *Бүлмәнең җыелышы ярты татарча, ярты аурупача.* Г.Исхакый. *Эш сәгате беткәч, авылына баручы юлга чыга торган озын урам уртасыннан ярты йөгереп өенә ашыга.* М.Хуҗин

◊ **Ярты акыл(лы)** Акылсыз, тилемиле, уйлап эш итми торган. **Ярты җан к. ярты кеше**. *Ә ир-ат дигәнең – яралы ярты җан: Я кулсыз, я култык таяклы!* Ф.Гыйззәтуллина. **Ярты җан да юк** Беркем булмау, бер җан иясе дә булмау. *Артка карасам да юк, Алга карасам да юк: Каралтымда – барысы үлгән кебек. Кыштырдаган ярты җан да юк.* Ш.Маннур. **Ярты җанын алу** 1) Үлем хәленә китерү. *Аяк аска салып, тибеп-тибеп, ярты җанымны алдылар кыйнап.* Ш.Камал; 2) Бик нык куркыту. **Ярты җанын ярып бирергә әзер** Нәрсә эшләргә дә әзер булу. *Ул синең өчен ярты җанын ярып бирергә әзер.* Ф.Яруллин. **Ярты җаны чыгу** Бик авыр хәлгә төшү, зур кыенлыклар аша үтү. **Ярты кеше** Авырудан, борчудан көчсезләнгән, тормыш активлыгын югалткан, рухи төшенкелеккә бирелгән кеше. *Аңлыйсызмы, Фатих абый, ярты кеше мин! Минем көчем дә юк, шатлыгым да...* А.Алиш. **Ярты көрпә, ярты он** Булмаган, пешмәгән кеше яки өздереп, төгәл итеп әйтелмәгән сүз. **Ярты мәет** *к.* **ярты үлек**. *Егетнең тәне каткат туралганын, рухы сынып, ярты мәет хәлендә кайтып егылганын беләләр, белмәгәннәр ил мисалында чамалыйлар иде.* А.Гыйләҗев. **Яртыны кагу** Аракы эчү. **Яртыны сындыру** *к.* **яртыны кагу**. **Ярты пешкән, ярты чи** Сыйфатлы итеп, тиешенчә эшләнмәгән. **Ярты сүз белән** Кыскача гына, берничә сүз белән. *Ярты сүз белән аңлатса ни булыр иде?* А.Гыйләҗев. **Ярты сүздә** Сөйли башлаган килеш, сүзне тәмамламыйча. *Хикмәт шунда ки: бу хатның ахыры юк, ярты сүздә өзелеп калган...* Г.Гыйльманов. **Ярты сүздән** Бер-ике сүз әйтүгә, шунда ук. *Ул сорашып-нитеп тормады, безне ярты сүздән аңлап алды.* А.Тимергалин. *Бәлки, дуслык – кешене ярты сүздән аңлаудыр, сердәше булудыр?* А.Мансуров. **Ярты тиен дә тормый** Бернинди кыйммәте юк, бернигә ярамый. **Ярты төн** Төн уртасы, бик соң. *Авыл урамында гармун тавышлары ярты төнгә кадәр ишетелеп торды.* Н.Акмал. **Ярты үлек** 1) Каты авыру, авыр хәлдә яки үлем алдында. *Барыйны ярты үлек хәлендә Казанга хастаханәгә алып килеп салганнар икән.* З.Хөснияр; 2) Куркудан яки авыр кайгыдан туган халәт. *Син әҗәлең җиткәнчегә хәтле ярты үлек, ярты терек булып яшәрсең.* Әкият. **Ярты чакрымнан** Ерактан, әллә кайдан. *Аңа, улым, ярты чакрымнан бөгелеп сәлам бирәләр.* А.Гыйләҗев. *Капка-коймалар бизәкләп, буяп эшләнгән – ярты чакрымнан балкып тора.* В.Нуруллин. **Ярты эш** Эшли башлап ташланган, ахырына кадәр җиткерелмәгән эш; сыйфатсыз итеп аннан-моннан башкарылган эш. *Ярты эш йөзгә оят.* Мәкаль. **Ярты юлда** Берәр төрле эшне, гамәлне ахыргача җиткермичә, тәмамламыйча, башлаган килеш. *Күп кенә башлаган эшләре тәмамланмый ярты юлда кала.* А.Тимергалин. **Ярты юлда атын тугару** Авырлыкларга каршы тора алмыйча, максатыннан баш тарту, ниятеннән кайту. **Ярты яклы булу** Паралич сукканнан соң тәннең нинди дә булса бер әгъзасы үз функциясен үтәүдән, хәрәкәтләнүдән тулысынча яки өлешчә туктау

**ЯРТЫ́-ЙОРТЫ** *рәв.* **1.** Җитәр-җитмәс, аз-маз, аннан-моннан, беркадәр. *Лазареттан лазаретка күчереп йөртә*

*торгач, врачлар аның сәламәтлеген ярты-йорты рәтләгән булалар.* Ш.Камал

**2.** *с. мәгъ.* Тиешле дәрәҗәдә булмаган, рәтсез, юньсез. *Һәр авылга олуг мәктәп салмак кирәк. Укытырга җанлы хәлфә алмак кирәк. Ярты-йорты уку илә эш чыкмады – Ихлас куеп дәресләрдә калмак кирәк.* Г.Камал

**ЯРТЫЛАЙ** *рәв. к.* **ятрылаш**. *Нәсимәләрнең почмак тәрәзәсеннән ак пәрдә ятрылай ачылып, кызыл чәчәкле кына гөле күренүгә, Гәрәйгә канат кунгандай булды.* С.Сабиров

**ЯРТЫЛА́У** *ф.* 1) Ярты өлешне бетерү, яртысына җитү. *Бик тыйнак кылансалар да, пәрмәч тавын яртыладылар, өчәр чынаяк чәй чөмерделәр.* Казан утлары

2) Билгеле елларның яртысын яшәү, вакытның ярты өлешен уздыру

**ЯРТЫЛАШ** *рәв.* 1) Яртысы кадәр; икедән бер өлеше кадәр. *Каршыда мәчет тора иде. Дамир, күп уйлап тормыйча, аның яртылаш ачык ишегеннән атлап керде.* И.Хуҗин. *Тәрәзәләрне инде яртылаш кар өеме күмеп китте.* З.Кадыйрова

2) Бераз, өлешчә. *Хөсәен абзыйның төсе дә гадәттән тыш бер кыяфәткә кергән, күзләре яртылаш йомылган, йөзендәге җыерчыклар тагы да арткан төсле иде...* Г.Гобәйдуллин. *Әле менә Бүздәккә баргач кына да, искитмәле хәлне яртылаш үзе күреп, яртылаш ишетеп кайтты.* В.Имамов

**ЯРТЫЛЫ** *с.* 1) Яртыга тигез булган. *Ялгызның ястыгы яртылы... Парлының мендәре уртаклы.* Ф.Дәүләтгәрәева

2) *күч. гади с.* Тиле-миле, акылга җиңел; аумакай

**ЯРТЫЛЫК** *и. гади с.* **1.** Бер шешә аракыга җитәрлек акча. *[Тәлгать] Районда кассир вазифасын эләктереп алгач, нәфес дигән юньсез нәрсә котырына да китә. Бер генә яртылык алам да хезмәт хакымнан кире куям, дип уйлады [ул] башта.* С.Поварисов

**2.** *с. мәгъ.* Бер шешә аракы алырлык, шуңа җитәрлек, шуңа дип аерылган. *Яртылык акча бир әле*

**ЯРТЫШАР** *сан* Һәрберсенә нәрсәнеңдер яртысы тиюен белдергән бүлү саны. *– Хәзер яртышар алмагызны үзара алышыгыз да янә бербөтен итеп кушып карагыз, – дигән.* В.Имамов

**ЯРТЫШАРЛАП** *рәв.* Ярты-ярты итеп, бөтенне тигез ике кисәккә бүлеп. *Алмалар яртышарлап киселгән*

**ЯРУ** *ф.* 1) Берәр бөтен каты әйберне нык итеп ваклау, таралып торырлык итеп таркату; тарту. *Тирә-күрше чуваш, мукшы авылларыннан да килеп, аның [Динмөхәммәтнең] тегермәнендә ярма ярганнар.* Г.Шәйхи

2) Ике яки берничә кисәккә бүлү, турау. *Туры сүз таш яра.* Мәкаль. *Гапгади көнкүреш, урак уру, утын яру кебек ябай гамәлләр арасында искитәрлек сихри көчләр яши.* Р.Батулла. *Шуннан бәрәңге утырту өмәсе дә җитә. Баздан күмәкләп бәрәңге чыгару, бакча башында бәрәңге яру. Ике-өч көн яралар, ике-өч көн утырталар.* М.Яһудин

3) Буйдан буйга кисү, буйга кисеп чыгару; телү. *Кайдадыр такта яралар, ахрысы, түгәрәк пычкы зырылдавы ишетелә.* Г.Әпсәләмов. *Матильда чәй әзерләде, Рәмил икмәк кисте, берсе мичкә утын тутырды, икенчесе чыра ярды.* К.Кара

4) Каты, очлы, үткен һ.б.ш. нәрсә белән кисү, яра ясау. *Ниндидер каты нәрсә белән сугып сул як яңагын ярганнар.* Н.Фәттах

5) *мед.* Операция ясау; кисеп эчен ачу. *Ярасын ярырга пәке бирсәгез икән.* М.Хуҗин. *Мәетне ярып караганнан соң, мәрхүмнең чыннан да йөрәк авырулы булуы расланган.* Р.Вәлиев

6) Вату, җимерү, бөтенлеген бозу. *Савыт-саба яру, чәйнек, чынаяк вату, чүлмәк-тәпән аударуларның исәбе-хисабы да юк.* Ш.Камал. *Таяк белән башыңны сугып ярам бит.* Д.Салихов

7) Җирне сөреп яки казып эз салу, чокырлы юл ясау. *Гөлзәрә, иртәнге чык белән буразна ярып, бәрәңге өя.* М.Әхмәтшина

8) Кабыгыннан арындырып, төшен ашау. *Өстәл тирәсендә хатын-кызлар чикләвек ярала р.* Һ.Такташ. *Кыздырылган көнбагыш ярганын күреп, түбәдәге күгәрченнәр Сөмбеләнең аяк астына күчте.* К.Кәримов

9) Урталай ерып, як-якка аралап сукмак салу, юл сабу, йөрерлек, барырлык итү; ерып хәрәкәт итү, аерып бару. *Озакламый көймәбез, беренче дулкынны ярып кереп, бер дулкыннан икенчесенә сикерә-сикерә, чайкалырга тотынды.* Г.Рәхим. *[Карлы] Юлны, яныл-пешеп, һаман да Габделбәр белән Валентин яра.* А.Хәсәнов

10) Берәр мәйданның, киңлекнең уртасыннан үтү; туп-туры бер башыннан икенче башына кадәр сузылу. *Кузовына кызыл кирпеч төягән КрАЗ Олы урманны ярып узган тигез асфальттан ыжгырта гына.* Э.Касыймов

11) Берәр нәрсәне урталай кисеп, икегә бүлеп үтү. *Шул мизгелдә иртәнге күктән түбәнтен генә яшен ташы очып узды, аның якты эзеннән түгәрәк аланны кып урталай ярган куш салават күпере пәйда булды.* А.Тимергалин

12) Яфрак чыгару, чәчәк ату, ачылу. *Бакчаларда кошлар сайравы, агачларның яфрак ярып чәчәк аткан чаклары җитте.* А.Нәҗми

13) Кояш, җил, су тәэсир итеп, җәрәхәтләр барлыкка китерү (мәс., ирендә, кулда, аякта). *Җил ярган йөз, арыган күзләр...* Р.Гаташ

14) Һавада кисеп алуга охшаш кискен хәрәкәт ясау

15) *күч.* Бик кискен яңгырау, тавыш нык ачык булып таралу, яңгырап китү. *Күп тә узмады, кинәт яман әче сызгырган тавыш һаваны ярды.* Г.Рәхим. *Аскы урамны ярып, баядан бирле берәү тимер чүки: әллә бу араларда худка киткән кул арбасына кыршау суга, әллә күчәр тимерли.* А.Гыйләҗев

16) *күч. сөйл.* Кыйнау, дөмбәсләү. *Мәнә синең күк чакта акыл бирүче булмаган. Тотып ярган булсалар, аңлаган булыр идем, мөгаен!* А.Гыйләҗев

◊ **Ярып керү** 1) Нинди дә булса ис көчле булып килү, нык сизелү. *Әчкелтем әрем исе борынын ярып керде.* З.Хөснияр; 2) Нинди дә булса тавыш ачык ишетелү. *Сәгать өчләр тирәсендә үк күрше әтәчләренең әче тавышы колакны ярып керде.* Г.Гыйльманов. **Ярып салу** 1) Дөресен яшермичә чатнатып әйтү. *Хөрмәт карт сүзен озайтып, уйларын әйләнгечтән уратып тормады, шундук турысын ярып салды.* Г.Гыйльманов; 2) Башкача сүз әйтергә урын калдырмаслык итеп җавап бирү. *Сәгыйтьҗан Шаһбаз мирзаның сөйләп беткәнен дә көтмәде: – Могтәбәр мөселманнар белән көрәшәсегез килсә, мәчеткә җомгага йөрергә кирәк, Шаһбазгәрәй морза, – дип ярып салды.* Ә.Фәйзи

**Яра башлау** Ярырга тотыну. *Иртән тору белән, кияве утын яра башлады, кызы бәрәңге бакчасын утарга менеп китте.* М.Яһудин

**Яра бирү** Яруын дәвам итү. *– Эшләр шәптән түгел, – диде Матвей, селтәнә-селтәнә туң каен кискәләрен яра биреп.* Казан утлары

**Ярып алу** Кинәт, кыска гына яру. *Исхакның ышанмый торуы күзенә чыкты бугай, Хөсәен кулы белән кискен генә һаваны ярып алды.* А.Гыйләҗев

**Ярып бетерү** Ахырга кадәр барысы да яки барысын да беткәнче яру. *Урманның иң матур көне егерме бишенче майда булды – бу көнне урман яңа аткан чәчәкләр белән тулы иде, агачлар яфрак ярып бетергән, нарат-чыршылар ылыс төсләрен яңарткан иде.* М.Хуҗин. *Күрәсеңме, бөтен эшләрне эшләде: утынны ярып бетерде, такталарны ышкылап, койманы какты.* З.Хәким

**Ярып җибәрү** Кинәт яру. *Иң яхшысы – кискен хәрәкәт белән шешне ярып җибәрү.* М.Маликова

**Ярып кую** Алдан яру, ярып әзер итү. *– Көчең кая куярга белмәсәң, Йормаш бабайга утын ярып куй! – диде Кәпәч.* Р.Батулла

**Ярып ташлау** Тиз генә яру. *Хәлим булмаган шул, былтыргы кебек, калын-калын утын кисентеләрен эһ тә итми ярып ташларга...* Г.Гыйльманов

**Ярып тору** Һәрвакыт, гел яру; әле, хәзер яру. *Яшь бөркетләр канат ярып тора, Оялар буш түгел кыяда.* Ф.Яруллин

**ЯРУ́С** *и. сканд.* 1) Тамашалар залында берсе өстендә берсе катлар ясап урнашкан ложалар, креслолар рәте. *Әһә, коррида президенты махсус келәмнәр белән бизәлгән ярус ложасыннан, ак яулык селкеп, тамашаны башларга ишарә ясаган икән!* Р.Фәйзуллин

2) Югарыга таба кабатланып барган рәтләрнең берсе. *Итәк кокеткадан һәм һәрберсе 20 см киңлектәге дүрт ярустан тора; яруслар бер киңлектә булса, тегү-кисү уңайрак, тукыма да азрак тотыла.* Сөембикә

3) Этаж, кат. *Кызу төзелеш башланган, әүвәлге көндә – беренче, икенче көндә – икенче каты, ярусы һәм башкалары салынган.* М.Хәсәнов. *Рус һәм башка милли архитектуралар белгече профессор В.В. Егерев әйтүенчә, Сөембикә манарасы, ярусларының кырт кискәндәй баскычланып менүе белән, рус дини корылмаларыннан һәм аларның төзелеш стиленнән нык аерылып тора.* Р.Фәхретдинов

4) *геол.* Бөтен үсешнең бер геологик гасыры дәвамында тупланган тау токымнарының утырма катламы. *Монда Уфа ярусы кызыл балчык һәм ком баганалары рәвешендәге борынгы континенталь катлаулар булып күренә.* Алабуга нуры

**ЯРУ́СЛАП** *рәв.* Яруслар ясап, ярус-лар рәвешендә. *Ә [кунакханәнең] башлары диңгез читеннән югары күтәрелгән текә калкулык битенә кат-кат яруслап салынган.* Р.Мөхәммәдиев

**ЯРУ́СЛЫ** *с.* 1) Яруслары булган. *Күп ярусլы суган кыякларының очларында чәчәк һәм орлык урынына өстә суганбашлар (бүлбечекләр) үсеп чыга.* Безнең гәҗит

2) Яруслап ясалган, катлы. *Уңайлы, дүрт ярусլы теплоход Казаннан Санкт-Петербургка кичкә таба китә.* Ф.Тарханова

3) Ярус-ярус булып урнашкан. *Тау битләренә ярусլы түтәлләр ясалган*

◊ **Ярусլы ысул** *бот.* Агач кәүсәсен формалаштырганда ботакларның билгеле бер санда булуын һәм билгеле бер ара калдырып урнашуын таләп иткән ысул. *Ярусլы ысул белән формалаштырганда, алмагачның ябалдашлары кәүсәдә бер-берсеннән 60–80 сантиметр арадагы ике яки өч ярустан тора.* Бакчачылык

**ЯРУТ** *и. бот.* Әвернәчәчәклеләр семьялыгыннан өскә таба тармакланып киткән туры сабаклы, эллипссыман яфраклы, бергә тупланган вак ак чәчәкле, түгәрәк кузаклы берьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* **ярутка**. *Ярут --- яр уты дип тә, яра уты дип тә аңлатыла ала.* Р.Әхмәтьянов

**ЯРЧЫК** *и.* 1) Бомба, граната, снаряд шартлаганда кителеп очкан кисәк; кыйпылчык. *Сугышта снаряд ярчыгы тиеп гармунын челпәрәмә китергән – гармун аны үлемнән саклап калган.* Р.Вәлиев. *Атасының сугыштан кайтып төшкән көнен, аның, билендәге ярчык кузгалудан куркып, сак кына, бөкрәя төшеп атлап йөрүләрен хәтерли әле ул.* Д.Булатова

2) *күч.* Нинди дә булса бербөтен әйбернең, күренешнең, вакыйганың кечкенә өлеше, кисәге. *Авыл ызбасында керәшен туе – чал тарихның нәни ярчыгы...* Я.Игәнәй. *Ул Монтана штатындагы дакота кабиләләренең берсендә юлбашчылар булып торган нәсел ярчыгы булган.* И.Хуҗин

**ЯРЧЫКЛАНУ** *ф.* 1) Ярчыклар барлыкка китереп ваткалану, вак-вак кисәкләргә таркалып ваклану. *Бәллүр ваза идәнгә төште дә, ярчыкланып, төрле тарафларга сибелде*

2) Аерым-аерым өлешләргә бүленү, яргалану. *Синең газиз гомереңә, сиңа бары тик бер, бер генә тапкыр Аллаһы Тәгалә тарафыннан бүләк итеп бирелгән яшәешең, шундый зур-зур кисәкләргә ярчыкланып кыскарып тора.* М.Юныс

**Ярчыкланып бетү** Тәмам, бик нык ярчыклану. *Тальяны снаряд ярчыгы тиеп ярчыкланып беткән, ә солдат үзе исән калган.* Өмет

**Ярчыкланып калу** Нинди дә булса берәр сәбәп нәтиҗәсендә ярчыклану. *Ярчыкланып калды тирән эзләр Катып яткан соры дуенда.* Ш.Мөдәррис

**Я́Р ЧЫПЧЫГЫ** *и. зоол.* Яр чыпчыклары семьялыгыннан чыпчыктан бераз зуррак, сырты яшькелт күк, түше күгәрек җирән төстәге кош; балыкчы тургай; *русчасы:* **зимородок**. *[Эльза:] Без – елга акчарлаклары, шуны да онытма. [Луиза:] Әллә яр чыпчыклары микән?* Р.Мингалим

**Я́Р ЧЫПЧЫКЛАРЫ** *и. күпл. зоол.* Ракшасыманнар отрядыннан зур башлы, озын, туры томшыклы, кыска муенлы, кыска аяклы уртача зурлыктагы яисә вак кошлар семьялыгы; *русчасы:* **зимородковые**

**ЯРЫ** I *и.* **1.** 1) Үсемлекләрдә, тереклек организмында берәр әгъзаны каплап алып, өслек ясап торган катлам; элпә. *Операция барышында тагын Юматшаның ике кабыргасы сынганлыгы, үпкә ярысы ертылып, үпкәсенә кан сауган булуы беленде.* Г.Әпсәләмов. *Табиблар, эч ярысы ялкынсынган, үлеге инде эчәкләренә таралган, дигән диагноз куйдылар...* Ә.Хәсәнов

2) Берәр нәрсәнең юка катламы. *Шундый чакларда аның күңелләре җирседе, күз кабаклары дымсу томан ярысы белән капланды.* Н.Фәттах. *Яшь ярысы аша бага бахыр Ут алдырган авыл ягына.* И.Диндаров

**2.** *с. мәгъ.* Элпә белән генә капланган; кабык белән капланырга өлгермәгән, җитлекмәгән. *Яры йомырка*

**ЯРЫ** II *и.* Нинди дә булса урын, ниндидер җир. *– Әллә башны алып бербер яры чыгып качасы инде? – дип мыгырданды ул.* А.Хәсәнов. *Җавап бирми, әллә [Хикмәт бабай] берәр яры киттеме икән?* А.Гадел

**ЯРЫЙ** *кис.* **1.** *мод. сүз к.* **ярар**

**2.** *кис. мәгъ.* «Я, шулай булсын да ди» мәгънәсендә кулланыла. *Ярый, язгы чәчү бетмәгән: Сабитның вакыты да булмасын ди.* А.Гыйләҗев. *Ярый, болары, бәлки, шаяру гына да булсын ди.* Б.Рәхимова

**3.** *хәб. сүз мәгъ.* Мөмкин, рөхсәт, була. *Менә иртәгә кызарып кояш чыгар, су өсте тын булыр, кармак алып барсаң да ярый.* А.Алиш. *– Дөньяның бар почмагында төгәл үтәлә торган тайга законы буенча, бередә тап бул-*

*ган ашамлыкларга үзеңнән соң ни дә булса калдыра алсаң гына кагылырга ярый, – диде.* А.Хәсәнов

◊ **Ярый әле** Эшнең, хәлнең, шартның башкача булмавына канәгатьлекне, тынычлануны белдерә. *Ярый әле даруын үзе белән йөртә: халат кесәсеннән тиз генә ак төймәне алып кабуга, бераз җиңеләйткәндәй итте.* А.Хәйретдинова. **Ярый инде** Кыенлык белән генә, теләмичә генә ризалашуны белдерә. *Ярый инде, хәерле булсын, Мифтах хәзрәтнең сүзен тыңлап, улыңны [хезмәткә] алып калсам калыйм инде.* К.Тинчурин. **Ярый ла** Сөйләмгә нәрсәгә дә булса ышанып бетмәү, икеләнеп, шикләнеп карау төсмере өсти. *Ярый ла эш барып чыкса уңайга.* Г.Тукай. *Ярый ла, партия җитәкчеләре булып, булдыклы, намуслы һәм гадел кешеләр генә урнашса.* Безнең гәҗит

**ЯРЫЙСЫ** *хәб. сүз* **1.** Канәгатьләнерлек; әйбәт, тиешле дәрәҗәдә. *Язгы ташкын шәп булып, тугайда су озак яткангамы, печән быел ярыйсы.* Г.Ибраһимов. *Егет болай ярыйсы: гәүдәгә нык кына, үзе җитез-елдам хәрәкәтләнә.* З.Мурсиев

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Үзе бәйләнгән сүздәге үзлекнең, күләмнең гадәттәгедән артыграк булуын белдерә; шактый, байтак. *Аның да сәяхәтләрдә күп йөреп, ярыйсы таушалган рюкзагы буш түгел.* А.Хәсәнов. *Кайчандыр төз нараттай булган Каюмны авыл тормышының авырлыгы ярыйсы бөккән.* А.Әхмәтгалиева

2) Тиешенчә, куелган таләпләргә туры килерлек. *Либреттоның теле әдәби яктан ярыйсы эшләнгән, уңышлы гына хор һәм арияләр очрый.* М.Җәлил

**ЯРЫЙСЫЛАНУ** *ф.* 1) Хәле уңайлану, рәтләнү, яхшыру. – *Хәлең ярыйсылана инде, лазаретка кергәндә, температураң кырык бер дә биш иде, – диде.* С.Йосыпов. *[Замана] Миңа соңга табарак үзе болай ярыйсыланды.* Ю.Сафиуллин

2) Бераз әйбәтләнү, яраклы, ярыйсы булу, яраРлык килеп чыгу. *Соңгы язган иншаң ярыйсыланган*

**Ярыйсылана бару** Акрынлап, азазлап ярыйсылану. *Шушы араларда редакциягә янучы гаиләнең кызлары Наталья Тихонова килде һәм әтисенең хастаханәдән чыгарылуын, хәле ярыйсылана баруын җиткерде.* Тәтеш таңнары

**Ярыйсылана төшү** Бераз, берникадәр ярыйсылану. *Икенче, өченче тапкыр күреп ясагач, рәсем бераз ярыйсылана төшә.* Г.Гобәй

**Ярыйсыланып килү** Соңгы вакытта ярыйсылану. *Авыруның хәле ярыйсыланып килә*

**ЯРЫК** и. **1.** 1) Ярылудан, аерылып китүдән барлыкка килгән тар гына ачыклык. *Ярык кайда, җил шунда.* Мәкаль. *Җил иясе бит ул кайда тели, шунда йөри ала: иң тар ярыкка да керә ала, иң биек агач башына да менә ала, иң тирән чокырга да төшә ала...* Г.Гыйльманов

2) Ябылып бетмәүдән, бераз ачылып китүдән барлыкка килгән ачыклык. *Ул өйгә ничек килеп кергәсен кабат күз алдына китерде дә, келәгә басып, авыр капканы этте. Барлыкка килгән ярыктан, кысылып, ишегалдына үтте.* А.Мансуров

**2.** *с. мәгъ.* Ярылган, ярылып киткән. *Күне буе җилдә чайкалып, әле дә хәлгә килеп бетмәгән шыгырдавык билле ярык усак тавышланып алды.* А.Гыйләҗев

◊ **Ярык барабан** Кирәгеннән артык мактанып, үз мөмкинлекләрен артык күпертеп сөйләүче кеше. *Кунакларның аны [Көяне] юньләп тыңламауларыннан: «Бу ярык барабан сүзен кайчан бетерер икән?» – дип торуларын сизенде.* А.Алиш. **Ярык быргы** *к.* **ярык барабан**. *Офыкта даһиларыбыз күренмәсә дә, үзләрен бөеккә санаучы ярык быргылар пәйда булып тора.* А.Тимергалин. **Ярык тагарак янында калу** Зурга өметләнеп, кечкенә әйбердән дә мәхрүм калу. *Әмма ләкин буш хыяллар, ялган өметләр белән гомер кичереп, үзең дә сизмичә, ярык тагарак янында калуың мөмкин бит.* Р.Вәлиев

**ЯРЫ́К-ЙӨРЫК** *җый. и.* Һәртөрле ярыклар. *Көз башы үзен сиздерә: яңгырга ияреп салкынча җил килеп җиткәч, ул, алачык төбендә генә тукталып калмыйча, бөтен ярык-йорыктан, кысылып булса да, эчкә керергә азаплана.* Г.Гыйльманов

**ЯРЫКЛЫ** *с.* 1) Ярыгы булган, ярык ясалган. *Аның башында бала башлыгына охшашлы бүрек, кулларында уч төбе ярыклы бияләй – барысы болан тиресеннән.* Н.Ихсанов

2) Ярылып киткән, ярылган. *Ашханәдә кырыйлары кителгән, ярылган, эмале чатнаган савыт-саба куллану, ризык әзерләгәндә, прессланган фанердан, пластмассадан эшләнгән, ярыклы агач куналарны файдалану тыела.* Сабантуй

**ЯРЫЛАНУ** *ф.* Яры белән каплану

**Ярыланып килү** Ярылана башлау. *Тавыкны җиренә җиткереп, бисмилла әйтеп суйдылар, сарыга каршы имләп пешерделер. Корсагында ярыланып килгән --- йомыркаларын да кызганып тормадылар.* Р.Рахман

**ЯРЫЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **яру**. *Утын ярылып өеп куелды*

2) Ярык барлыкка килү, буйга аерылу. *Бер капчык ярылып, юл буена бәрәңге чәчелгән.* А.Гыйләҗев. *Түшәмдәге яктырткыч плафоннарның ник берсе исән калсын! Барысы да ярылып, ватылып, челпәрәмә килеп беткән.* Р.Ибраһимов

3) Салкыннан, эсседән, корылык һ.б.ш.дан чәрдәкләнү, чатнау, тетелү. *Яшь патшаның беренче явы бик уңышсыз бетә: өстенә су чыккан Идел бозы ярылып, бик күп пушка һәм пищальләр, сугышчылар су астына китә.* М.Хәбибуллин. *Җир ярылып кипте, үләннәр үсүләреннән туктады, дөньясы үзе кара корылыкта торып калды.* З.Мурсиев

4) Шартлап, бик вак кисәкләргә таркалу, ярчыклар барлыкка килү. *Һавада лып та лып ядрәләр ярылып, өзелеп калган болыт кисәкләре сыман төеннәр күренде.* Г.Кутуй. *Авиабомба ярылып, яңа бер ярчык аягын яралагач та югалып калмый бит!* Р.Могыйнов

5) Берәр сәбәптән шартлап сыну, аерылып, кителеп төшү. *Ташның йөзенә язылганы башында, ахырында язуы беткән; таш ярылып төшкән.* К.Насыйри. *Карт өянкенең ябалдашы шартлап ярылып төште.* А.Нәҗми

6) Бәрелүдән, сугылудан яралану, җәрәхәт алу. *Гусар чыбыркы сукканнан ярылып канга баткан кулын ике бот арасына тыгып чайкала-чайкала утырган хәлдә акыра иде.* З.Зәйнуллин. *Башка бәла килде дип, башны ташка орып булмый, орсаң да, таш ярылмый, баш ярыла, ди.* З.Хөснияр

7) Икегә бүленеп юл, ачыклык хасил булу, икегә аерылу. *Ул бүлмәнең дивары ярылып, бер юл булды. Егет ул юлдан тышка чыкты.* К.Насыйри. *Ул арада халык төркеменең бер очы, урталай ярылып, авыл ягыннан килүче Госманга юл бирде.* Г.Гыйльманов

8) Чәчәк, яфрак ачылу, ату. *Кечкенә генә камфер агачының бөреләре ярылып, юка гына, йомшак кына яфракчыклар кояшка таба башларын суза башлады.* Г.Рәхим

9) Кояш, җил, су ашаудан ирен, кул, аяк тиресендә авыртулы җәрәхәтләр барлыкка килү. *Ул көнне Тимерханның язгы җилдә ярылып кубалакланган, күптәннән елмаю белмәгән бите көләчләнеп яктырган иде.* М.Мәһдиев. *Җәй*

*көне яланаяк йөргәнлектән, аякларга чеби чыга: җилдә тире ярылып, җәрәхәт барлыкка килә.* Ф.Галиев

10) Биттә, тәндә җыерчыклар хасил булу. *Эльвирның маңгае җыерылды, иреннәре кысылып, шома яңакларында чокырлар урынына буразналар ярылып керде.* М.Маликова

11) Көн туу, таң ату. *Таң ярылып, кояш Каф тавы артыннан баш күтәреп, дөнья яктыргач, падишаһ тәхетенә килеп утырды.* К.Насыйри

12) *күч.* Кычкырып сөйләү; ачу белән сөйләү, ачулану, пыр тузу

13) *күч.* Нык яңгырау, кайтаваз тудыру. *Дача ягыннан: – Тиз бул, кофе өлгерде, – дигән тавыш ишетелде; ул урманга ярылып чыңлап китте.* Г.Исхакый. *Күк ярылып чатырдый, тау шаңгырый.* Дәрдемәнд

14) *күч.* Бик нык авырту, нык сызлау. *Башның ярылып авыртуын --- исәпкә алмаганда, бар да тәртиптә кебек.* Ф.Дәүләтбаев

◊ **Ярыла язу** 1) Ачудан, гарьлектән тыела алмаслык халәткә керү, үзен чак тыеп калу. *Ачудан ярыла яздым: башкалар сөйләсеннәр дә инде, кайсы белеп өрә, кайсы – берни белмичә, әмма Галинең, Кадыйровның, Баязит абыйны кызганам, диюенә кем ышанган?!* А.Гыйләҗев; 2) Эш күплектән нишләргә белмәү, өлгерергә тырышу. *Ә татар теле мөгаллимәләре, кырыкка ярыла язып, программа үтәргә тырыша.* Мәдәни җомга; 3) Бик каты кычкыру. **Ярылып үләргә җитешү** Ярсудан, ачудан, гарьлектән яки эш бармаудан нишләргә белмәү. **Ярылып яту** Аермачык булып күренеп тору. *Аның карашында үтә зур газап, чарасызлык ярылып ята иде.* А.Мансуров. **Ярылырга җит(еш)ү** *к.* **ярыла язу**. *Эш бу тикле тыгылып килгән елларда кешегә өмәгә йөрү түгел, үз эшең өчен дә берүзең кырыкка ярылырга җитәсең.* Г.Ибраһимов. *Старостa хурлануыннан ярылырга җитеште, нидер әйтергә җыенган сыман, авызын бер ачты, бер йомды.* Г.Бәширов

**Ярыла бару** Торган саен ныграк ярылу; барысы да рәттән ярылу. *Аның [каенның] тузы кытыршылана, ярыла бара.* Р.Зарипов

**Ярыла башлау** Ярылырга тотыну. *Атна-ун көн дигәндә, ул бозлар шартлый, ярыла башлар.* Р.Мөхәммәдиев

**Ярылып алу** Азга гына, вакытлыча ярылу. *Мәмдәьяр аһ итеп кала, болытлар кинәт урталай ярылып ала, күзләр чагыла, һәм көн тагын караңгыланып китә...* Ф.Яхин

**Ярылып бетү** Тәмам, бик нык ярылу; барысы да ахырга кадәр ярылу. *Йөзләрдән шабырдап тир ага, авыз эчләре тәмам кипшереп, иреннәр эссе җилдән ярылып беткән иде...* М.Галәү. *Ярылып бетмәгән утын түмгәкләре чүмәлә кебек өелеп ята.* Г.Гыйльманов

**Ярылып килү** Аз-азлап, акрынлап ярылу. *Таң да сызылып кына ярылып килә иде.* Р.Фәхретдинов. *Агач яфраклары Ярылып килә инде.* К.Булатова

**Ярылып китү** Кинәт ярылу. *Халыктагы ярсу гөбердәп кайнаган су шикелле мәнә-мәнә түгелә башлар, я булмаса казан үзе ярылып китәр сыман.* В.Имамов. *Шул вакыт аның каршында җир убылып, юк, дөнья урталай ярылып киткәндәй булды.* Г.Гыйльманов

**Ярылып тору** Һәрвакыт, бертуктаусыз ярылу; әле, хәзерге вакытта ярылган булу. *Сабит абыйсының ияге чыгынкырак икән, икегә ярылып тора.* А.Гыйләҗев. *Утлы ядрәләр, сазлыктан чыгып җиткәнче, әле монда, әле тегендә ухылдап ярылып торды.* З.Мәхмүди

**ЯРЫЛЫП** *рәв.* Аермачык, ап-ачык булып. *Хәтфә үлән арасында түмтүгәрәк булып тирмә эзләре генә ярылып күренә.* В.Имамов

**ЯРЫМ** *и.* **1.** Берәр нәрсәнең яртысы. *Кызга ул ярымы бастырылган, ярымы кулдан тутырылган кәгазь кисәген тоттырды.* Ф.Яхин

**2.** *сан функ.* Сан, микъдар, күләмне белдергән сүзләр белән килеп, шулардан аңлашылган бөтеннән тыш «тагын ярты» мәгънәсен белдерә. *Шул ике ярым-өч яшьләремдә төшкән фото сакланган.* А.Хәсәнов. *Болгар осталарының булат кылычларына, чакрым ярым оча торган утлы укларына, җиз калканнарына тиңнәр юк.* А.Гадел

**ЯРЫМ-** Кушма сүзләрең беренче кисәге: 1) Исемне белдергән сүзләр алдыннан килгәндә, «шул әйбернең яртысы» мәгънәсен белдерә. *Тирә-юне сыек яшел яфраклы юкә, каен агачлары белән ярымбоҗра сыман уратып алынган түгәрәк күл.* А.Вергазов. *Малайлар ярымтүгәрәк булып тезелешәләр.* А.Гадел

2) Матдәне, материалны белдергән сыйфатлар алдыннан килгәндә, «катнаш, башка компонентлар белән аралашкан, кушылган» мәгънәсен белдерә. *Кытат – Кытайдан кергән ярымъефәк киҗе-мамык тукыма.* К.Насыйри. *Монда аның күпме тапкырлар килгәне булды, күпме тапкыр шушы яшеллеккә төренеп утырган ярымагач, ярымташ йортлар өстенә карап торганы булгандыр.* Х.Ширмән

3) Сыйфатлар алдыннан килгәндә, аларда күрсәтелгән үзлекнең өлешчә дәрәҗәдә булуын белдерә. *Аның [көймәнең] төбенә әллә нинди кырмавыклар, ярымчерек төрле суүсемнәр, әкәмтөкәмнәр, бакакайлар да килеп ябыша.* В.Имамов. *Кама-Чулман буе урманнарын танырлык түгел, кайчандыр адәм аяк басарга кыймаган ярымкыргый, сихри урманнар юк инде.* Мәхм. Хәсәнов

4) Рәвешләр алдыннан килгәндә, үтәлү дәрәҗәсенең яртылаш, өлешчә генә булуын белдерә. *Шулай да Фарукҗан, ишегалдына аяк басуга, бер кырыйдагы ярымъевропача корылган озын йортны ачык шәйләде.* Т.Әйди

**ЯРЫМАВТОМАТ** *и.* **1.** Эшне автомат башкара, ләкин өлешчә кеше катнашын таләп итә торган механизм, аппарат, әсбап. *Бәлки, алар нибары ярымавтоматлар гынадыр?* А.Азимов

**2.** *с. мәгъ.* Шул рәвештә эшли торган. *Өч көпшәле ярымавтомат Бельгия мылтыгы Казанда берәү иде.* А.Хәсәнов. *Цехтагы җиһазлар ярымавтомат – шуңа күрә биредәге мәшәкатьнең яртысы кул көче белән башкарыла.* Безнең гәҗит

**ЯРЫМАТА́У** *и. к.* **ярымутрау**. *Мөхәммәд шаһ белән улы Әләлетдин янә Меңкышлак ярыматавында гына кавыштылар.* В.Имамов. *Совет авиациясе Балтыйк суларын контрольдә тотты, ярыматау портларыннан судноларның чыгуына ирек куймады Либава.* Казан утлары

**ЯРЫМБИШ** *и. иск.* Дисәтинәнең 1/3 өлешенә тигез булган элекке җир үлчәү берәмлеге. *Урман янындагы ике ярымбиш борчакны, яшел дип, матур көннәрдә җыеп алмаганнар иде.* А.Шамов

**ЯРЫ́М-ЙОРТЫ** *с.* **1.** 1) Аз гына күләмдә, җитәрлек булмаган, җитәрҗитмәс. *Өй эчендәге ярым-йорты яктылык, сүрән тоныклык күңелне тырнады, рухны басты.* Н.Хәсәнов

2) Булыр-булмас дәрәҗәдә, тиешенчә, кирәгенчә булмаган. *Мәрьямбикә карчык нәсел-кардәш булган бу ятим баланы үз йортына алды да, ярым-йорты тәрбия биреп, гимназиягә кертте.* Г.Ибраһимов. *Кешенең инануы вакытка да, мохиткә дә бәйләнмәгән, я*

*бар ул иман, я юк – ярым-йорты булмый.* К.Кара

3) Дөреслеге төгәл ачыкланмаган, анык билгеле булмаган. *Фарук мулла белән икесен дә Себергә җибәргәннәр, дигән ярым-йорты хәбәрдән башка берни дә билгеле түгел.* Г.Галиева. *Булганы да ярым-йорты легендага, риваятьләргә генә нигезләнгән иде.* С.Ибраһимова

4) Мәртәбәсез, абруйсыз. *[Әндиҗанда] Кулыннан һичбер эш килмәгән, һөнәрсез, театрдан хәбәре юк вә бернәрсәгә дә мөстәхикъ булмаган ярым-йорты кешеләр тарафыннан татарча театр уйналды.* Г.Исхакый

**2.** *рәв. мәгъ.* Аз-маз, түбән дәрәҗәдә, тулысынча түгел. *Ә немецчаны Тиммерманс ярым-йорты сукалый.* Г.Әпсәләмов. *Ни өчен башка цивилизацияләр җентекләп тикшерелгән дә, төркиләр тарихы шулай ярым-йорты гына өйрәнелгән һәм язылган соң?* С.Шәмси

**ЯРЫМТҮГӘРӘК** *и.* Түгәрәкнең яртысы. *Хан тәхете тирәсенә ярымтүгәрәк булып җырчылар, музыкантлар, шагыйрьләр, хәкимнәр һәм фәйләсуфлар тезелеп баскан.* А.Тимергалин

**ЯРЫМУТРА́У** *и.* Өч ягыннан су белән уратып алынган, дүртенче ягы материкка яки зуррак утрауга тоташкан коры җир. *Күп тә үтми, гуннар Перекопка җитәләр, ул вакытта валлар белән ныгытылмаган ярымутрау аша готларның тылына чыгалар.* М.Хәбибуллин. *Кола ярымутравын барыбыз белә: әгәр кучереп тартсаң, аның эченә Көнбатыш Европаның берничә дәүләте сыярлык.* А.Хәсәнов

**ЯРЫМҮТКӘРГЕЧ** *и. физ.* **1.** Электр тогын өлешчә үткәрә торган матдә. *Ярымүткәргечләрне үткәргечләрдән аеру өчен, температурага бәйле рәвештә аларның үткәрүчәнлекләре ничек үзгәрүен тикшереп карарга кирәк.* Физика

**2.** *с. мәгъ.* Электр тогын өлешчә үткәрә торган. *Түгәрәккә йөрүче укучылар, «Радио» журналыннан схемалар туплап, заманча ярымүткәргеч детальләр урнаштырып, магнитофонның шактый өлешен ясадылар.* Татарстан яшьләре

**ЯРЫМШАР** *и.* 1) Шарның яртысы һәм шул формадагы әйбер. *Әл-Әкъса мәчетенең ярымшар формасындагы алтынсу гөмбәзе әллә кайдан балкып тора икән.* Казан утлары

2) Җир шары һәм күк йөзенең шартлы рәвештә бүленгән икедән бер өлеше, ярты якларның берсе. *Әлкәй мәктәбендә беренче тапкыр ярымшарлар картасын, глобусны күрсәтүче дә Шәйхелислам хәлфә булган.* Маяк

**ЯРЫШ** *и.* Беренчелекне алу, башкаларны узып китү, гомумән югары нәтиҗәләргә ирешү өчен көрәш. *Ул чакта илдә ниндидер ярыш, көндәшлек рухы хөкем сөрә иде: кем теге яки бу чараны затлырак, байрак итеп үткәрә ала.* Р.Мирхәйдәров

**ЯРЫШТАШ** *и.* Үзара ярышучы кешеләрнең яки коллективларның берсе. *Ул ярышташының кайда ялгышуын, кайда алдан күреп җиткермәвен, нәрсәне күздән ычкындыруын һәрчак барлап чыга.* Кызыл таң

**ЯРЫШУ** *ф.* Нинди дә булса өлкәдә беренчелекне алу, алга чыгу өчен яки башкалардан артта калмаска тырышып көрәшү. *Ирләр, берничә төркемгә бүленеп, ярышып, таңнан таңга чаклы эшли торган булып киттеләр.* Т.Галиуллин

**Ярыша башлау** Ярышырга тотыну. *Ләкин, гөнаһ шомлыкка каршы, өченче елда анларга кара күзле бер башкорт малае килеп кушылды да моның белән беренчелектә ярыша башлады.* Г.Ибраһимов

**Ярышып алу** Бераз, берникадәр ярышу. *Авылда әтәчләр ике тапкыр дөнья күтәреп ярышып алдылар.* А.Тимергалин

**Ярышып карау** Сынау, белү максаты белән ярышырга омтылыш ясау, ярышырга тырышу. *Татарның аш-суын әзерләүдә, бар, син аның белән ярышып кара!* А.Хәлим

**Ярышып килү** Элек-электән, һәрвакыт ярышу. *Безнең «Чулпан» колхозы күрше «Кызыл флаг» хуҗалыгы белән ярышып килде.* Ватаным Татарстан

**Ярышып тору** Һәрвакыт, гел ярышу. *Клявлинодагы [кикбоксчы] дусларыбыз белән даими ярышып торабыз.* Дуслык

**ЯРЫШУЧЫ** *и.* к. **ярышчы**. *Эскәмияләрдә утырган халык ярышучыларны дәртләндереп тә, үчекләп тә кычкыра, көлешә.* М.Маликова

**ЯРЫШЧЫ** *и.* Ярышта катнашучы. *Ялгыз атлы ярышчы, яргак тунлы көрәшче.* Мәкаль

**ЯСА** *и. монг. тар.* Чыңгызхан тарафыннан игълан ителгән дип фаразланган, феодализм чоры хокук нормалары тупланган феодаль хокук кануннары мәҗмугасы. *Киләчәктә магул патшалыгы бердәм, катгый канун буенча идарә ителәчәк дип, Чыңгызхан үзе кереш сүз ясады. Ошбу кануннар төпләмәсенең исеме Яса булыр.* В.Имамов

**ЯСАК** *и. тар.* Феодаль бәйлелектә булган кешеләргә җан башыннан салына торган салым. *[Идел буена] Болгарлар килгәнче, ак чәчле, кысык күзле, озын сакаллы, тәбәнәк кенә буйлы, урманнар эчендә аучылык һәм игенчелек белән көн күрүче финнар булганнар; ләкин алар хәзерге көндә инде болгар ханының кул астында, аңарга ясак түлиләр.* Г.Гобәйдуллин

**ЯСАКЛЫ** *с. тар.* Ясак түли торган. *[Казан ханлыгында] Дәүләтнең ясаклы халкының чагыштырмача азчылык өлешен шәһәрләрдә яшәгән һөнәрче һәм сәүдәгәрләр тәшкил иткән.* Б.Хәмидуллин

**ЯСАКЧЫ** *и. тар.* 1) Ясак түләүче. *Ташкичү авылы җирләренең зур өлеше казнаныкы булып, ул аны оброк статьялары төсендә, ягъни билгеле акчага, дәүләт крестьяннары дип йөртелгән – элекке ясакчы, сука башыннан салым түләүче, йомышлы кешеләрдән чыккан крестьяннарга бирелгән.* Тарих

2) Ясак җыючы

**ЯСАЛМА** *с.* **1.** 1) Табигый булмаган, кеше тарафыннан ясалган, корылган; сонгый. *Елганы туфрак өеме белән киртәләп, авылны икегә бүлеп торган ясалма сулык ясадылар һәм аны күл дип атадылар.* Я.Шәфыйков

2) Ялган, чынга охшатып эшләнгән. *Ул арада ясалма күн белән тышлангән өстәлдәге телефон шалтырады.* С.Шәрипов

3) *лингв.* Кушымча ялгау, сүзләрне кушу юлы белән барлыкка китерелгән. *Ясалма сыйфатлар төрле кушымчалар ярдәмендә исемнән, фигыльдән һәм кайбер башка сүз төркемнәреннән ясала.* Ф.Хисамова. *Ясалма ярымкалькаларның беренче компонентлары гадәттә интернациональ сүзләрдән тора.* Р.Мөхиярова

4) *күч.* Күрсеннәр өчен генә эшләнгән, риялы, ялган. *Гомер буе шуларга буйсынырга мәҗбүр булып, ялган, ясалма тормышта яшәргә туры килде.* Ә.Еники. *Озатучылар, ясалма елмаю белән кулларын болгап бераз янәшә баргач, кайтыр юлга борылдылар.* М.Маликова

**2.** *рәв. мәгъ.* Табигый булмаганча, гайре табигый рәвештә. *Әдәп кагыйдәсен саклыйм дигән булып, һаман үземне ясалма тотарга мәҗбүрмен.* Ә.Еники

**ЯСАЛМАЛЫ** *с. к.* **ясалма**. *Ясалмалы була белмәдем шул, Бай булдым шул ихлас хисләргә...* Ф.Дәүләтгәрәева. *[Әнсар] Тавышына вәкарьлекне ясалмалы итеп, кирәгеннән артыграк өстәде.* Казан утлары. *Ясалмалы, икейөзле рәхмәт сүзе...* Кызыл таң

**ЯСАЛМАЛЫК** *и.* Ясалма булу сыйфаты, табигый булмау. *Нәкъ менә елмая төшеп, чөнки аның елмаюында ниндидер бер киеренке ясалмалык сизелә иде.* А.Тимергалин. *Бу туган телнең табигый агышына комачаулый, ясалмалык кертә.* Р.Юсупов

**ЯСАЛМАЛЫЛЫК** *и. к.* **ясалмалык**. *«Алмам», «җимешем» сүзләрендә төчелек, ясалмалылык бар.* Г.Гыйльманов. *Әмма кат-кат мактау, гел бер үк сүзләрне кабатлау ясалмалылыкка китерә.* Ә.Закирҗанов

**ЯСАЛУ** *ф.* 1) *төш. юн. к.* **ясау**. *Берничә ел элек анда бронзадан ясалган истәлек тактасы да куелган иде.* З.Мәхмүди. *Синтаксик, ягъни сүз кушу ысулы белән парлы, кушма һәм тезмә рәвешләр ясала.* Ф.Хисамова

2) Барлыкка килү, формалашу. *Таулар ясалу. Тау токымнары ясалу*

**Ясала бару** Системалы рәвештә ясалу. *Гомумән алганда, бүген аңлатуларынча, бәйгегә һәр районда ай саен да, квартал саен да нәтиҗәләр ясала барачак.* Ватаным Татарстан

**Ясала башлау** Ясалырга тотыну. *Мөгаллим әфәнденең фатирында репетицияләр дә ясала башлады.* Гали Рәхим

**Ясалып бетү** Ахыргача, тулысынча ясалу. *Кечкенә генә куыш ясалып беткәч, Иван Иванович шунда тынычлап ял итте, һәм, төнге ябалаклар тавышы булмаса, ул әле, бәлки, кояш чыкканга кадәр дә кузгалмый ятар иде.* А.Расих

**Ясалып килү** Электән үк, даими рәвештә ясалу. *Анда [Казанда] хәрби һәм пассажир самолётларының иң яңа төрләре ясалып килде.* И.Хәйруллин

**Ясалып тору** Һәрвакыт, гел ясалу. *Кушымчалар ярдәмендә яңа берәмлекләр, аеруча атама-терминнар ясалып тора.* И.Низамов

**Ясалып чыгу** Башыннан ахырына кадәр ясалу. *Мәкальләр халкыбызның тарихын да, язмышын да, аның табигатькә, җәмгыятькә мөнәсәбәтләрен дә, рухи төзелеше ничек ясалып чыгуын да, ышануларын һәм дөньяга карашларын да, --- милли зәвыгын, тәләкләрен, әхлакый һәм башка сыйфатларын да чагылдыралар.* Н.Исәнбәт

**ЯСАЛЫШ** *и.* Ясалу, эшләнү рәвеше. *Аның башыннан: «Тавышы да, ясалышы да нәкъ минем гармун икән», – дигән уй йөгереп үтте.* Р.Гариф. *Биш һәм алты компоненттан торган атамалар күп түгел, әмма ясалыш модельләренә төрлелек хас.* О.Галимова

**ЯСАНУ** *ф.* 1) *кайт. юн. к.* **ясау**. *Ул каралты-кура тирәсендә көнозын нидер ясанды*

2) Бизәнү, матурлану, төзәтенү. *Таулар иле, бәйрәм көткән кебек, Ничек матурланган, ясанган.* Р.Миңнуллин. *Көндез эш киемнәреннән ничектер килбәтсез күренгән кызлар, егетләр хәзер бәйрәмчә киенгән, ясанганнар һәм күңелле музыкага җиңел хәрәкәтләр белән парлашып бөтереләләр.* С.Сабиров

**Ясана башлау** Ясанырга керешү. *Ак атларга атланып, комач ябынып, ялангач кылыч тотып, ханкапкадан Казанга керер өчен, икесе дә ясана башлады.* Р.Батулла

**Ясанып алу** Бераз, аз гына ясану. *Хәзер үк китәбез, тукта, бераз бизәнеп, ясанып алыйм да.* Г.Гомәр

**Ясанып кую** Алдан ук ясану. *Кыз, көннең үткәнен көтә алмыйча, шул аулак өйгә барырга бизәнеп, ясанып куйган иде.* Г.Ибраһимов

**Ясанып тору** Әле, хәзерге вакытта ясану. *[Лилия] Якутның сумкасын ачкан да көзгө каршында иреннәрен буяп ясанып тора.* А.Гыйләҗев

**ЯСА́У** I *ф.* 1) Нинди дә булса әйбер эшләү. *[Нечкәбил: Безне кешеләр] Җылы өй ясап үрчетәләр, тәмле ширбәт эчертеп үстерәләр.* А.Алиш // Ни дә булса җитештерү

2) Тасвири сәнгать әсәрләре иҗат итү, тудыру; сызымын, контурын сызу. *Көннең калган өлешен җиргә акбур белән рәсем ясап уздырдым.* Н.Гыйматдинова. *Кыргый кеше үзенең дошманын үтерергә теләсә, балавыздан курчак рәвешендә әлеге дошманның сынын ясап, утка ыргыткан һәм, шуннан соң дошман үзе дә шул ук язмышка дучар була, дип ышанган.* Л.Җамалетдинов

3) Нәрсә дә булса оештыру, үткәрү. *Әңгәмәнең ахыры кызны озату чараларын кайгырту, туй ясау турындагы киңәшләр белән тәмам булды.* Г.Ибраһимов. *Валера озату кичәсе ясап тормады, югыйсә әнисе: «Ясыйк, дусишләреңне чакырырсың», – дигән иде.* З.Хөснияр

4) Пешерү яки ашау өчен, азыкны берәр ысул белән эшкәртү, билгеле бер рәвешкә китерү. *Харисов ул елны Югары Осланда кәҗә сөтеннән кымыз ясап эчеп, шунда ай ярымнар чамасы дачада торды.* Г.Толымбай. *Мичкә казның баш, аяк, канат һәм эчке әгъзаларыннан, аңа бераз бозау ите дә кушып, зур гына шулпалы бәлеш ясап тыкты.* Г.Галиева

5) Чынаякка кайнар су коеп әзерләү. *Әни табынга тегесен-монысын өстәп тора, чәй ясап бирә.* Г.Бәширов. *Әминә аңа, инде менә ничәнче тапкыр, каты итеп кофе ясап китерде.* Н.Акмал

6) *сөйл.* Тегеп, сатып алып һ.б. юл белән булдыру. *Син алай юкка акча әрәм иткәнче, миңа күлмәк яса!* Г.Исхакый. *Бераз юнәеп, кеше арасында күренерлек өс-баш ясагач, болар [ир белән хатын] туган илгә бер әйләнделәр.* Г.Ибраһимов

7) Эш төрен, процессны белдергән исемнәр һәм исем фигыльләр белән килгәндә: шул эшне башкару, үтәү. *Әмма бәрмә дулкынның хикмәтләрен тәҗрибә ясап ачыклау – утә катлаулы һәм читен эш.* Т.Әйди. *Бирeдә [бүлекчәдә] Г. Камалның «Йолдыз»да басылган мәкаләләренә бер күзәтү ясап чыгу гына максат итеп куелды.* М.Мәһдиев

8) Кайбер абстракт исемнәр белән килгәндә: нинди дә булса эш-хәлнең нәтиҗәсенә ирешү. *Карьера ясау*

9) Берәр хәл тудыру, китереп чыгару. *Төрек әйтә икән, ди, әгәр дә, дип әйтә икән, ди, шул мордар урысны җиңсәм, иң элек мөселманга җиңеллек ясап, җир бирермен, имана түләттермәм.* К.Тинчурин. *Тора-бара тормыш үз эзенә төшәр, Язилә апага мәшәкать ясап йөрмим, дип уйлады.* Г.Вәлиева

10) Берәр фикергә килү, нинди дә булса карар чыгару. *Ахырда миңа түләргә ясадылар. Өч айда мин фәлән-фәлән мең акчаны өстәлгә салырга тиеш идем.* Н.Гыйматдинова

11) Нинди дә булса сыйфатка ия итү, берәр үзенчәлеген булдыру, үзенә хас үзлек бирү. *Шәпеш [хәлфә] дөньяда бер кешене дә белемле ясамады, аңарда укыган шәкертләр үзе шикелле томана, дорфа булып чыктылар, адәм рәтле эшкә ярамадылар.* Ә.Фәйзи. *Алар кешелек дөньясын коллык богауларыннан азат итәр өчен, аны бәхетле ясар өчен яшәгәннәр.* Г.Кутуй

12) *лингв.* Сүз, форма барлыкка китерү, ясалышта катнашу

13) *күч.* Берәр затны яки берәр нәрсәне нинди дә булса башка бер хәлгә китерү, әйләндерү, берәр төрле сыйфатта тәрбия кылу. *Атасы, укымышлы вә уртача бер авыл бае булып, улын укымышлы ясарга ният иткән һәм ул ниятенә ирешкән дә иде.* Ш.Камал. *Ә сугыш – олы сынау. Ул күпләрне үзгәртте, чыныктырды, кеше ясады.* А.Гыйләҗев

14) *күч.* Төсен, формасын, кыяфәтен яки гомумән эчтәлеген үзгәртү. *Юрагач та йолдызлар, Алдарга теләп тәкъдирне, Миннән ерткыч ясады.* Р.Зәйдулла. *Әнә бит әнкәсе тиргәгән саен: «Йөрмә шул тауга, эчендәге рухлары чыгып, сихерләп дивана ясарлар», – дип тирги.* Г.Гыйльманов

15) Берәр төрле тәэсир итү. *Йогынты ясау. Басым ясау*

◊ **Ясап куйган кебек** 1) Бик оста, булдыклы, бер дигән. *– Акыл өйрәтергә сез барыгыз да ясап куйган кебек, – диде Марсель.* М.Әмирханов; 2) Бик матур, бернинди кимчелексез. *Аның урынына буй-сын, гәүдә ясап куйган кебек.* М.Әмирханов

**Ясап алу** Тиз генә ясау. *Әни килгәч, мәҗлес ясап аласы булыр.* Л.Лерон

**Ясап бетерү** Ахырга кадәр ясау, тулысынча ясау. *Айдашлар нәселе гомер бакый күршеләргә әйбер сорап кермәде. Айдашлар, тозлары булмаса, тозсыз ашадылар. Иләкләре булмаса, Айдаш карт ясап бетергәнне көттеләр.* Р.Батулла

**Ясап йөрү** Озак вакыт ясау белән шөгыльләнү; әле, хәзер, сөйләү моментында ни дә булса ясау белән мәшгуль булу. *Беркөн шулай иртән иремә чәй ясап йөрим.* А.Гыйләҗев

**Ясап карау** Ясарга тырышу, ясарга омтылу. *Менә нәрсә, Айтуган токымы, пароходны үзегез ясап карагыз әле.* Г.Гобәй

**Ясап кую** Алдан ясау; ясап калдыру. *Шуңа күрә Себердә яшәгән кадими элгәрләребезнең ташбака сыны өстенә мәңгелек күк йөзе картасын ясап куюлары гаҗәп тоелмый.* А.Тимергалин

**Ясап ташлау** Кинәт, һич уйламаганда ясау; аннан-моннан, тиз арада ясау. *Менә шул чагында моннан хәбәре дә булмаган бер надан килеп чыга һәм яңа ачышны нәкъ менә шул ясап ташлый.* А.Тимергалин

**Ясап тору** Һәрвакыт, гел ясау; әле, хәзер ясау. *[Фәләх] Күбрәк бүтәннәр сөйләгәнне, бүтәннәр мактанганны тыңлап, шуннан үзенә гыйбрәт алып, нәтиҗә ясап тора иде.* В.Нуруллин

**Ясый бару** Торган саен ныграк, күбрәк ясау. *Бу вакытта һаман көчәя барган мәгърифәтчелек хәрәкәте, милли-әхлакый идеяләр мәдрәсә тормышына, шәкертләр аңына сизелерлек йогынты ясый бара.* Ш.Камал

**Ясый башлау** Ясарга керешү. *Бу чорда, бигрәк тә соңгы палеолит чорында, кешеләр төрле сурәтләр, нәкыш үрнәкләре, хәтта скульптур фигуралар ясый башлаганнар.* К.Гыйззәтов

**Ясый бирү** Ясавын һаман дәвам итү. *Ярату, мәхәббәт дигән хистән мәхрүм булган, бәгыре ташка әйләнгән Саниягә кеше аерылса ни дә, кушылса ни – исе дә китми, сихерен ясый бирә.* Сөембикә

**Ясый төшү** Тагын да бераз өстәп, күбрәк ясау. *Ләкин хикәясе[нең] уңышлы ахырына басым ясый төшкәндә, тагы да яхшы булыр иде.* К.Вахит

**ЯСА́У** II *с.* **1.** 1) Бер кимчелексез, арада аерылып торган, иң яхшы. *И-и-и, илаһи кәрим, Гыйниятуллаң ясау егет булып үскән икән, ди.* З.Зәйнуллин

2) Матур бизәлгән, күркәле; чиста, пөхтә, таза, нык. *Бик мул яшәде: йортҗирләре ясау, өстәле безнең төшләребезгә дә кермәгән ризыклардан сыгылып торды.* Маяк

3) Яхшы, өр-яңа; бәйрәмдә кия торган, купшы, ыспай, көяз. *Йөз-кыяфәтенә караганда, матросның киеме, авыл карчыклары әйтмешли, бик ясау – чиста, үтүкләнгән, үзенә таманлап киселгән, тегелгән, беренче генә елын хезмәт итми иде булса кирәк.* Р.Кәрами

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Матурлап, чиста, пөхтә итеп. *Ләкин бу инде хәзер клуб түгел, ә мәдәният йорты, ике катлы, таштан салынган, эче-тышы ясау итеп бизәлгән.* Р.Кәрами

2) Өр-яңадан, яхшыдан; бәйрәмчә, купшы, ыспай, көяз итеп. *Баскычта, чәчләрен яулык эченә тыга-тыга, бер карчык күренде, аның артында ясау киенгән килен чырае балкыды.* Х.Камалов

**ЯСИГЪ** *и. дини к.* **ясту**. *Ясту һәм ясигъ намазы лексемалары Идел буе татарларына гына хас.* А.Тимергалин. *Мәккә каласын бераз тамаша кылып йөргәч, тагы такси яллап, Минага кайттым. Ахшам узган, ясигъ җитмәгән иде әле.* Ә.Зарипов

**ЯСИН** *и. гар. дини* Үлем түшәгендә яткан кешенең гөнаһларын кичерүне һәм аның терелүен сорап, аның янында яки вафатыннан соң рухына багышлап укыла торган сүрә. *Гөлйөзем әбине якнан-якка бәреләсугыла торган, Алла, Алла, дип ыңгыраша торган рәвештә тапты, бик ихлас берлән «Ясин»ны укыды; бик озын иттереп дога кылды.* Г.Исхакый. *Өч мөселман, иңгә-иң торып, 25 ел буе бергә каторга михнәтләрен кичә. Аларның һәр икесен [Юлайны һәм Салаватны] Канзафар, «Ясин» укып, соңгы юлга озата.* В.Имамов

◊ **Ясин чыгу** 1) Үлем түшәгендә яткан яки инде мәрхүм булган кешенең гөнаһларын кичерүне сорап, «Ясин» сүрәсен башыннан ахырына кадәр уку. *Тукта, Өммегөлсем башы түнүдән уйлап та өлгермәгән түгелме: Әкчин мөселман авылы булмагач, теләсә кайсы төштә ул каберне кем казыр да, кем «Ясин» чыгар?* А.Хәлим; 2) Нәрсәнең яки кемнең дә булса бетәчәге, бетәргә тиеш булуына ишарә мәгънәсендә кулланыла. *Әлеияр өстендә утырган көемә үк син миңа ясин чыгарга җыенасыңмы әллә, сатлык Торгын?!* В.Имамов

**ЯСКАНУ** *ф. диал.* Нәрсәгә дә булса дәртләнү, нык омтылу, теләү, ашкынып тору. *Тел – диңгез. Бер ясканып кына аның тирәнлегенә төшеп, киңлекләрен иңләп бетереп булмас.* Р.Фәйзуллин. *Еллар буе сагынып, авылына кайтырга ясканып яшәгән кеше ни өчен соң туган җирен ташлап китәргә мәҗбүр?* Р.Батулла

**Ясканып тору** Һәрвакыт, гел яскану. *Ә тегеләре игенченең барлык уңышларын үзләренеке итеп күрсәтергә ясканып торалар.* Ф.Садриев

**ЯСКУ** *ф. диал. к.* **яскану**. *Әллә нинди вәхши кошлар төрле яктан яскыйлар.* М.Гафури

**Я́СЛЕ** *и. рус* Кече яшьтәге балаларны тәрбияләү учреждениесе. *Кышкы салкында, әче буранда, иртәнге сигездә бер кулыма китаплар кыстырып, икенче кулыма бала күтәреп, яслегә ашыга идем.* Г.Кутуй

**ЯСМИН** *и. гар. бот.* Зәйтүнчәләр семьялыгыннан ак төстәге хуш исле чәчәк ата торган декоратив куак үсемлек, гөл; *русчасы:* **жасмин**. *Ясмин һәм ак тәмәке хисне, рухны кытыклый торган исләрен бер-берсеннән уздырып аңкытырга тырышалар.* Г.Рәхим. *Чәчкә, син узган урамнардан ясмин исе килә.* А.Гыйләҗев

**ЯСМЫК** *и.* **1.** 1) Кузаклылар семьялыгыннан яссы түгәрәк орлыклы иген культурасы; *русчасы:* **чечевица**. *Кайсыбер урыннарда яз көне уҗымны да*

*бозып, ясмык, карабодай, борчак кебек әрсез ашлыкларны чәчүчеләр булгаласалар да, сабан ашлыгы вакытында яңгырлар булмау белән чыгар-чыкмас ук корып, кибеп бетте.* К.Тинчурин. *Казан ханлыгы халкының төп хуҗалык итү гамәле игенчелектән гыйбарәт булган. Җирне парга калдырып эшләү алымы кулланылган, арыш, бодай, солы, арпа, борай, тары, карабодай, борчак, ясмык чәчкәннәр.* Р.Фәхретдинов

2) Шул үсемлекнең азык итеп файдаланыла торган орлыгы. *«Мәрхаба, хуш килдең, мин бараем, сезгә тәгам китерәем», – дип, алдына дүрт икмәк китереп куйды, ясмык шурпасы алмага китте.* К.Насыйри. *Хатыны казаннан ясмык чумарын соса башлады.* И.Гази

**2.** *с. мәгъ.* Шул үсемлекнең орлыгына охшаган. *Хәзрәт, бикасап казакиенең кесәсеннән юка гына ясмык ачкычыны алып, ишекнең Америка системасында эшләнгән бигене ачып, ишектән яртылаш кереп, мөсафирга йөзе илә әйләнде.* Г.Камал

◊ **Ясмык кадәр дә** Бик кечкенә генә дә, аз гына да. *Тик хәзер минем аңа ясмык кадәр генә дә ачуым юк иде.* Г.Бәширов. **Ясмык камыры** Җебегән, булдыксыз кеше

**ЯСМЫКЛАНУ** *ф.* Ясмык формасын алу, түгәрәк өслеге батып, ялпак рәвешкә керү. *Аның болай да ач яңаклары тагын да суырылган, күз төпләре бакыр тәңкәдәй ясмыкланган, әүвәлге мөлаем йөзендә чак кына да чырай калмаган иде.* Ф.Мансуров

**ЯСМЫК ПЫЯЛА** *и. к.* **линза**

**ЯССЫ** *с.* 1) Кабарып, почмакланып, сыртланып тормаган, өсте җәенке, тигез булган. *Татар авылларында гадәттә су буенда урнашкан тимерчелек таштан яки саманнан төзелеп, ут чыгу куркынычын кимету өчен, яссы түбәсенә туфрак та җәелгән тәбәнәгрәк кенә бинадан гыйбарәт иде.* А.Тимергалин

2) Җәенке, ялпак. *Кыяр тавыннан бәләкәй арба белән яссы, юка ташлар ташыдылар.* А.Гыйләҗев

**ЯССЫЛЫК** *и.* 1) Яссы, җәенке өслек. *Һәрбер җисемнең өч мәсахәсе, ягъни өч тарафы бардыр ки: озынлыгы, яссылыгы вә һәм тирәнлеге.* К.Насыйри

2) *күч.* Өлкә, сфера, тармак; мөнәсәбәтләр даирәсе; караш ноктасы. *Р.Нуриев хезмәтендә татар драматургиясенең гасырдан артыкка сузылган тарихындагы текст үзгәреше диахроник яссылыкта тикшерелә.* А.Әхмәдуллин

**ЯССЫ́ ТАБАН** *и. мед. к.* **аю табан**. *Аның яраларына карагач, табиб шакката: шушындый яссы табан белән ничек шул кадәрле ерак арага йөгерешкә чыгарга була?* Биектау хәбәрләре

**ЯСТҮ** *и. дини* 1) Кояш баеп шәфәкъ кызыллыгы бетүдән башлап, таң яктылыгы җәелгәнчегә кадәр дәвам итә торган вакыт арасы. *Кадер кичне, ястү вакыты җитү белән, мин аны [Фазулланы], җитәкләп, мәчет янына алып мендем.* Г.Бәширов. *[Хәмит:] – Ястү тирәләренә килеп җитәргә тырышыгыз! – дип кычкырып калды.* Мәхм. Хәсәнов

2) Шул вакытта дүрт рәкәгать итеп укыла торган бишенче намаз. *Имам К.Рәимовның --- сүзлегендә --- «ястү» сүзе дә теркәлгән һәм «йокыга ятар вакыт» дип аңлатылган. Кыскасы, ястү намазы – ястыкка ятар алдыннан укыла торган намаз булып чыга.* А.Тимергалин

**ЯСТЫК** *и.* **1.** 1) Эченә каз мамыгы, йон һ.б.ш. тутырылган зур мендәр. *Кыңгыраулар тагып, ястык салып, Кыз алырга килдек җилдереп.* Җыр. *Мендәр, ястык, түшәк өемнәре дә ал, кызыл, зәңгәр, яшел, сары, тагы да әллә күпме төсләргә җепләр белән чигелеп эшләнгән япкычлар белән ябып куелган иде.* С.Поварисов // *диал.* Гомумән мендәр

2) Түшәк, ятак. *Әфган тәмугының җиде катын үткән солдатның йокысы ястык тели димени?!* А.Гыйләҗев

**2.** *с. мәгъ.* Мамык таулары кебек күпереп кабарып торган, зур өем-өем. *Син килерсең Ястык-ястык көртләрне ярып.* Н.Гамбәр. *Хәлим, мәтәләмәтәлә, күк катындагы ястык болытлар өстенә килеп төшә...* Г.Гыйльманов

**ЯСТЫКЧЫ** *и. этн.* **1.** Туйга әзерлек барышында кызга бөтен эштә ярдәм итеп, булышып торучы кызларның берсе. *Кыз янында ястыкчылар булган шикелле, егет янында да кияү егетләре була.* Казан утлары

**2.** *с. мәгъ.* Туй әзерлекләрендә кызга ярдәм иткән. *Үзара нидер сөйләшәсөйләшә, кызның әйберләрен – күлмәген, яулыгын, калфагын, тасмаларын, тагын әллә нәрсәләрен карыйлар, барлыйлар, куялар, кыскасы, кәләшне киендерергә әзерләнәләр. Бу кызларны ястыкчы кызлар дип йөртәләр икән.* Ә.Еники

**ЯТ** *с.* **1.** 1) Чит, туган булмаган, кардәшлек мөнәсәбәтендә тормаган. *Борыннан борын килгән гадәт буенча, балаларга ят кеше булмасын диеп, Хәлил [үлгән хатынының тумадан-тума сеңеле] Әсмага өйләнде.* В.Ильясов

2) Билгесез, моңарчы күрмәгән, белмәгән, таныш булмаган. *Хөршидәттәй ялгыз түгел, олы якта, самавыр янында, бер ят әби дә утыра.* А.Тимергалин. *[Овчарка] Ят кеше күрү белән, ямьсез ырылдый башлый, тешләмәк, таламак булып, аның өстенә ыргыла.* А.Хәсәнов

3) Чит; чит илгә караган, башка илнеке булган. *Динекәев Хәбибулланың өч улы ят җирләрдә мәңгегә ятып калганнар.* А.Хәсәнов. *Римлылар, башка ят ил кешеләрен атаган шикелле, германнарны да «варварлар» дип атаганнар.* Борынгы заман тарихы

4) Таныш булмаган, аңлашылмый торган. *Бераздан абыйның көйләп-көйләп китап укуы яңадан колакка килеп керә. Өй эченә моңарчы ишетелмәгән әллә нинди сәп-сәер ят сүзләр сибелә башлый.* Г.Бәширов. *Ят телдәге дәртле җырлар арасында әледән-әле танышын сузып җибәрәләр.* М.Маликова

5) Гомуми кагыйдәләргә, кануннарга каршы килгән, нормага туры килмәгән, алар белән ярашмаган; сөйләүче фикеренә каршы килгән. *Кешелеккә ят, бөек инстинкт канунына каршы булган бу гамәлен аклау өчен, ул фәлсәфә дә корып куйган.* А.Әхмәдуллин

6) Гадәти саналмаган, табигый булмаган. *Әле колагына ниндидер ят авазлар ишетелә, күзенә әллә нәрсәләр күренә.* М.Кәбиров. *Барак эчендә әчкелтем бер ят ис йөзә.* А.Хәсәнов

**2.** *и. мәгъ.* 1) Үз булмаган, чит кеше. *Балам бу минутта нишли: еламыймы, чирләмиме, ятлар җәберләмиме, дип уйламый булмас.* М.Маликова

2) Дошман. *Эшләр болай дәвам итсә, көннәрдән бер көнне Болгарны ятлар яулар, акыл ияләрен дар агачларына асарлар, юләрләрдән, бау иштереп, бер елгадан икенчесенә су ташытырлар.* М.Хәбибуллин

**3.** *хәб. сүз мәгъ.* Хас түгел, табигыйлыкка туры килми, гайре табигый. *Яшьләр исә кечкенә генә җәберне дә онытмый, аларга гафу итү хисе дә ят.* А.Хәсәнов

◊ **Ят бавыр** Чит кеше, үз кеше түгел; башка нәсел кешесе. *Сезнең өчен ят бавыр мин.* В.Нуриев

**ЯТАГАН** *и.* 1) Сырты чыгынкы, үткен йөзе батынкы ягында булган кәкре кылыч төре. *Ауга түгел, яуга бара диярсең: иңнәренә-биленә бар кора-*

*лын аскан. Җәя, садак, ятаган кылыч, хәнҗәр, гөрзи...* В.Имамов

2) *муз.* Төрки халыкларда борынгы кыллы чиртмә музыка уен коралы. *Унике кыллы кече гөслә, егерме дүрт кыллы зур гөслә һәм гөсләгә охшаш уен коралы ятаганның булуы турында мәгълүматлар бар.* Р.Гыйләҗев

**ЯТАК** *и.* 1) Йокы урыны. *Кайчандыр сөешеп кавышып, ике-өч ел бергә ятак уртаклашып яшәп тә аерылып киткән ярлар кебек, авыр аерылыштык.* А.Гыйләҗев

2) Йокы урынына түшәлгән урын-җир әйберләре. *Якын әбием биргән зур-зур йомшак мендәрләр, каз мамыгыннан сырыган юрган, ятак өчен әзерләнгән юка түшәкләр – барысы да безнең урын-җирләргә күчеп бетте.* Э.Шәрифуллина. *Җылы, йомшак ятакларында изрәп, мес-мес йоклап яткан игезәк оныклары Айдар белән Хәйдәрне Галим бабай бүген бик иртә уятты.* Л.Лерон

3) Ятып йоклый торган йорт-җир җиһазы. *Миңзыя түтки инде сүнеп үк барган малайга шундагы сәке сыман ятак өстенә урын түшәде.* А.Хәлим. *Эчке якның ишеге ачылуга, агачтан ясаган киң ятак өстендә, мендәрләр арасында гы-гы килеп яткан бәләкәй баланың күләч йөзе күренде.* Г.Исхакова

4) Кояшта ятып кызыну өчен ясалган, күчереп йөртергә мөмкин булган пляж җиһазы. *Әлмәт шәһәр пляжында ятаклар, --- таганнар, пляж волейболы өчен җайланмалар түләүсез булачак.* Казан утлары

5) *сир.* Торак, яшәү урыны. *Имеш, аны үзенең авылдагы агач йортыннан шәһәрнең күп катлы ятагына күчләп кертергә итәләр.* А.Хәлим

6) Эт, песи өчен махсус әзерләнгән яту урыны. *Сырып тегелгән мәче ятагы*

**ЯТАКЛЫ** *с.* Ятагы булган, ятак урнаштырылган. *Бу поездда булган яхшы вагон да ятаклы өченче класс вагоны икән.* Г.Баруди

**ЯТАКХАНӘ** *и. иск.* 1) Тулай торак. *Хәзерге радиотапшырулар бинасында элек чуваш студентларының ятакханәсе булган.* Р.Батулла

2) Кунып чыгу йорты; йокы бүлмәсе. *Алдынгы карашлы бай бу мәдрәсә янында китапханә, шәкертләр, юлаучылар өчен кунакханә, ашханә, ятакханәләр дә кордырган.* Т.Әйди

**ЯТА́-ТОРА** *рәв.* 1) Бер ятып, бер торып. *Төрле төстәге ефәк җеп белән чиккән намазлыкны идәнгә җәеп, Габдулла бай шул келәм уртасына басты да, ята-тора намаз укый башлады.* М.Галәү. *Немецлар алмаш-тилмәш ята-тора киләләр.* С.Поварисов

2) Куна ятып, даими яшәп. *Иске мәдрәсәдә ята-тора дин белән фәнне бергә укып йөрүебез дә шул кышта тәмам булды.* Ә.Еники

3) Авырып, сырхаулап. *Яудан яраланып кайткан әтиләре ята-тора ике ел яшәгән дә дөнья куйган.* С.Сөләйманова

◊ **Ята-тора йөрү** Авыру, сырхаулау. *Яңа елның беренче өч көнен авырып, юньле эш тота алмыйча ята-тора йөреп уздырдым.* М.Әмир

**ЯТЕШ** *с. диал.* 1) Уңай, җайлы, ипле. *Ничек итсә итте: кычыткannан чагыла-чагыла, читәннең астында бер ятеш кенә тишекне зурайтып, икенче ягына үтә алды.* Х.Исмәгыйлев. *Яшеренеп тыңлау өчен, янәшәләрендәге куе зелпе куагы бик ятеш булып чыкты.* Казан утлары

2) Килешле, урынлы, төгәл туры килгән. *Карабашка Әрәм ил атамасы ныграк та ятеш әле.* Сөембикә

**ЯТЕШЛЕ** *с. диал.* Уңайлы, җайлы, ипле. *Үз урынын Кеше эзли еллар буена. Җанга ятешле бер урын табып, Шул почмакка барып сыена.* Ф.Дәүләтгәрәева

**ЯТИМ** *и. гар.* **1.** 1) Атасы яки анасы, яисә атасы да, анасы да үлгән бала; үксез. *Мин инде ятим икәнебезне, әти белән әниебезне беркайчан да, беркайчан да күрмәячәгебезне аңладым...* А.Тимергалин. *– Бер ятим иде инде алар, тагын, торган җирләреннән аерылып, икеләтә ятим булсыннармыни?! – дип үкседе хатын.* Н.Гыйматдинова

2) Таянычы, дусты, туганы, якыннары булмаган кеше. *Бар да бар, тик юк туганнар, мин ятим монда, ятим.* Г.Тукай

3) Башкалардан үзенең кимлеге белән аерылып торган йорт, гаилә һ.б.ш. *Мал-туарсыз ишегалды – баласыз йорт кебек ятим бит ул.* Г.Галиева

**2.** *с. мәгъ.* 1) Ата-анасыз калган, үксез. *Авыру яз көне башланып, җәй буе падишаһлык сөргәнгә, болгар халкының яртысын үтереп бетергән иде. Моның калган яртысының утыз фаизы ата-сыз-анасыз, карендәш-кабиләсез калган ятим балалар, яртысы эшкә ярамый торган карт-коры иде.* Г.Исхакый

2) Тәрбиячесез, караучысы булмаган, караучысын югалткан; хуҗасыз. *Кызыл түбәле өй ятим булып утыра, бакчадагы каеннар да мескенләнешеп саргайганнар.* Г.Рәхим. *Бу ятим кырларны эшкәртеп, бодай чәчкәнне күрәсе килә минем.* А.Гыйләҗев. *Өй түрендә тора ятим тальян гармун.* Л.Мөгътәсимова

◊ **Ятимнәр кышы** Көчле салкыннары булмаган, җылы кыш. *Быелгы кыш Ятимнәр кышымы соң? Табигатьнең ана булып Назлавы шушымы соң?* Ф.Җамалетдинова

**ЯТИМӘ** *и. гар.* Ятим кыз бала. *Зифа тәтәй минем әтинең энесенең кызы була. Ул сабый чагында ук ятимә калганлыктан, кияүгә киткәнче, безнең әти тәрбиясендә үскән.* Г.Бәширов

**ЯТИМЛЕК** *и.* 1) Ятим булу хәле. *Җырның беренчесе тәмамланганда, күп кешенең күзендә яшь була, чөнки «Герман» сүзе ата-бабадан килгән зур бәхетсезлек, ятимлек, толлыкны аңлата иде.* М.Мәһдиев

2) *күч.* Ялгызлык, ярдәмчесез булу хәле; тәрбия җитмәү, каралмау хәле

**ЯТИМХАНӘ** *и. гар.-фар.* Ятимнәр йорты. *Җәдидчелекнең асылын тәшкил иткән яңа кеше тәрбияләү проблемасын Р.Фәхреддин хыялында туган, мөселман ятим балалары өчен махсус салдырылган ятимханә аша тасвирлаган.* Безнең мирас

**ЯТИ́М-ЯТИМӘ** *җый. и.* Ятим балалар; ятимнәр, үксезләр. *Улым, безне нигә ялгыз калдырасың... Хәялием, әнекәең белән мин бәхеттән мәхрүм бит инде... Ятим-ятимә бит инде без...* М.Хуҗин

**Я́Т ИТҮ** *ф.* Чит күрү, читләштерү, үз итмәү. *Үз авылым, үз почмагым. Сыендырыр әле, ят итмәс.* Г.Бәширов

**ЯТКАЛАК** *и. сөйл.* 1) Ялкау, эшлексез, ятып кына торырга ярата торган кеше

2) Саулыгы булмаган, чирле кеше

**ЯТКЫЛЫК** *и. диал.* 1) Соңгылык, бала урыны

2) Көн уртасында көтүдәге малтуарны туплап ял иттерә торган күләгәле, җиләс яки сулыгы булган урын. *Яткылык: бер төбәктә ул – көтүнең төшкә туктау урыны – туплавык, ә икенче якта ул – соңгылык – карында бала урыны, ә өченче төбәктә – агым су җыелып торган җир.* Саба таңнары

3) Җирдәге су агымы, елга агып барган батынкылык; *русчасы:* **ложе**

4) *к.* **ятма** I (1 мәгъ.). *Рәсми мәгълүматлар буенча, республика территориясендә 60 тан артык төр*

*минераль чималны үз эченә алган өч меңнән күбрәк яткылык ачылган.* Кызыл таң

**ЯТКЫН** *с.* Эшкәртелми яткан; сөрелми калган; калдау. *Яткын җирләрне үзләштерү шаукымы --- узган иде, шуңа күрәме, аръяктагы бу урынга кызыгучы да, күз салучы да табылмады.* А.Гыйләҗев. *Урман төпләп, яткын җирләрне сөреп ясалган басуларда иген бик уңган.* Р.Газиз

**ЯТКЫРУ** *ф.* 1) *йокл. юн.* к. **яту**. *Ләйләне сәгать тугыздан да калдырмыйча яткырырсың инде.* Г.Кутуй. *Пациентны гадәттәгечә кичке сәгать унда урынга яткырдылар, һәм ул, башка көннәрдәге кебек, биш минуттан йокыга талды.* А.Тимергалин

2) Йоклау яки ял итү өчен урын әзерләп урнаштыру, урын бирү. *Авыру кешегә җылы булыр дип, мич башына яткырган идек без аны.* М.Гали. *Түрдә зур ятак өстенә түшәкләр җәелгән иде, шунда яткырдылар.* Р.Сәгъди

3) Кайда да булса тоту; тоткарлап тору. *Нәҗипне больницада нибары бер атна яткырдылар.* А.Гыйләҗев. *Миңлебайны ике атналап вакыт станица төрмәсендә яткырдылар.* Н.Яһудин // Кая да булса урнаштыру, кертү. *Хастаханәгә яткыру*

4) Вертикаль торган әйберне берәр нәрсә өстенә салу, кую. *Велосипедны сукмак читенә яткырып, йөгерә-йөгерә, болын чәчәкләре җыеп йөрде.* А.Вергазов

5) Аудару, сөрлектерү

6) Файдасызга тоту, озак саклау. *Әмма китапны укыгач озак яткырмагыз, китерегез!* А.Хәлим. *Хәзерге падишаһыбызның атасы Алексей Михайлович та оҗмахтай бай мондый далаларны ташландык хәлдә яткырырга теләмәде.* В.Имамов

7) Махсус тоткарлап тору, уздырмау. *Гаризаны шул килеш яткырганнар*

**Яткыра бару** Һәрберсен, һәр очракта, бер-бер артлы яткыру. *[Хәлим] Караватка яткыргач та әле ни өчендер өч мәртәбә урыныннан тормакчы булды, һәр торуында, хатыны аның күкрәгенә төртеп яткыра барды.* Р.Зәйдулла

**Яткырып кую** Яткырган хәлдә калдыру. *Шунда берсе, Әгъли дигәне, кулындагы шома саплы җиз балтасын яткырып куйды да билен язды.* Н.Фәттах

**ЯТЛА́У** *ф.* Хәтердән сөйләрлек итеп өйрәнү, хәтергә беркетү; оту. – *Мин кәгазьдән укырга яратмыйм, алай йогышсыз чыга, мин ятлап сөйлим, – ди иде.* Г.Бәширов. *Хәйям китапларын бар дөнья тиккә генә дога-аятьләр кебек ятлап укымыйдыр шул!..* Р.Фәйзуллин

**Ятлап алу** Тиз арада ятлау. *Зөһрә, ике дә уйлап тормыйча, шул доганы да ятлап алыр иде...* Г.Гыйльманов

**Ятлап бетерү** Барысын да, тулысынча ятлау. *География дәреслеген инде тоташтан ятлап бетердем диярлек.* В.Нуруллин

**Ятлап кую** Алдан ук ятлау. *Нәрсә әйтәсен әллә кайчан ук ятлап куйган инде югыйсә.* Г.Бәширов

**Ятлап чыгу** Башыннан ахырына кадәр ятлау. *Бөтен Коръәнне ятлап чыгам.* Т.Миңнуллин

**Ятлый бару** Һәрберсен ятлау. *Һәр сүзеңне ятлый барам.* Ч.Мусин

**ЯТЛЫК** *и.* Ят, чит булу хәле, үз булмаганлык. *Алай булгач, безнең арабызда ятлык булмасын, күңелләребездә бер-беребез хакында яманлык булмасын.* Татарстан яшьләре

**ЯТМА** I *и.* 1) *геол.* Файдалы казылмалар тупланган урын. *Махсус белеме буенча геолог ул, Татарстанда нефть ятмалары табуда күп эшләгән галим.* Ә.Еники. *Югыйсә бар иде заманнар: геологлар мондагы бетмәс-төкәнмәс хәзинәләр – файдалы жир асты казылмалары ятмасы хакында бөтен илгә шау килеп хәбәр иткән иделәр.* Р.Мирхәйдәров

2) Җыелып торган, өелеп яткан нәрсә; өем. *Яфрак белән капланган су ятмаларының күзенә генә басабыз.* А.Гыйләҗев. *Кар ятмасы күз алдында үсә, тыгызлана бара.* М.Галиев

**ЯТМА** II *с.* 1) Горизонталь. *Могҗиза белән исән калган ятма читән казыгында ат башы сөяге...* А.Гыйләҗев. *Ятма сызык*

2) Ятып, җиргә сырышып үсә торган. *Ятма сабаклы үсемлекләр*

**ЯТСЫНУ** *ф.* 1) Чит-ят булганга, танымаганга читләшү, чит итү, якын мөнәсәбәт күрсәтмәү. *Гали фикергә калып эндәшми тора, ике кечкенә кызчык, бер дә күзләрен алмый, бик ятсынып, аңар карыйлар.* Ш.Камал. *Улагыннан шулай башын алып, Ник ятсынып карый бу кашка?* Ш.Галиев

2) Чит, ят булып тоелу, электән белгән таныш билгеләр күрмәү, танымау. *Ятсынып карап торам: җирне-күкне, тирә-ягымны, заводны танымыйм.* А.Гыйләҗев. *[Бөркет баласы] Ятсынып, тирә-ягына каранды, тимерчыбыкны чукыды, акрын гына чыелдап куйды – яңа урынны килештермәде.* Ә.Әминев

3) Мөнәсәбәттә, карашларда якынлык югалу, ят кешегә, ят нәрсәгә әйләнү; бизү

**Ятсынып бетү** Тәмам, бик нык ятсыну. *Без бер-беребезгә ияләшә башлагач кына аерылышып китәбез дә икенче күрешкәнче тагын ятсынып бетәбез...* Ш.Галиев. *Әллә кешеләр икенчерәк, әллә үзебез, читтә яшәп, авылдан, кешеләреннән ятсынып беткәнбез?* И.Нәбиуллина

**Ятсынып кую** Кинәт ятсыну. *Я, могҗиза! – көлмәк иске, Ә мин яңардым кинәт! Ятсынып куйдым үземнән, Яшәреп киттем, димәк?..* Л.Шагыйрьҗан

**Ятсынып тору** Әле, хәзерге вакытта ятсыну. *Куй әле, Рәшидә, үз өеңдәге шикелле генә бул әле... Бу нинди ятсынып тору, килешмәгәнне!* Ә.Еники

**ЯТТАН** *рәв.* Хәтердән, күңелдән. *Таҗи Гыйззәт үзе язган пьесалардагы барлык рольләрне яттан белә иде.* К.Гыйззәтов. *Юк, [Гайникамал апа] китапны карап укымый ул, яттан, күңелдән укый.* М.Хәсәнов

**ЯТУ** *ф.* **1.** 1) Бөтен гәүдә белән өслек өстенә сузылган хәлдә булу (кеше һәм хайваннар тур.). *Линар, кул-аякларын таратып ташлап, комга чалкан яткан да күзләрен йомган.* М.Маликова. *Эштән кайттым, чебиләрнең берсе дә юк. Песи ашагандыр боларны дисәм, исем китте: карават янында мәче идәнгә сузылып яткан, барлык чебиләр аның өстендә, кырында җылынып яталар.* Безнең гәҗит

2) Баскан, утырган, чүгәләгән торыштан, гәүдәне сузып, горизонталь торыш алу (кеше һәм хайваннар тур.). *Песи минем янга сикереп менде, иркәләнеп алдыма сузылып ятты.* А.Гыйләҗев. *Хәлимә мизгел эчендә боз өстенә сузылып ятты, башындагы шәлен салып, аның бер очын суда бата-калка күренгән Һаҗәргә сузды.* А.Әхмәтгалиева

3) Ял итү яки йоклау максаты белән ятакта урын алу. – *Әйдәгез, ятарга вакыт ич инде, – дип, [хуҗа хатын] аларны бүлмәдән алып чыгып китте.* Т.Әйди. *Фатыйма килгәндә, инде өйдә ут сүнгән, бала белән хуҗалар йоклаган булды – олылар иртә ята шул.* З.Кадыйрова

4) Гәүдәне берәр якка яки берәр нәрсәгә таба авыштыру, авышу. *Закирҗанның кепкасы очкан, ул ат ялына ябыша төшәрәк алга яткан.* М.Мәһдиев

5) Берәр урынга куелган булу. *Әлбәттә, безнең арба төбендә үткер балта белән сөңге, ә Гани пәһлеваннның арбасында саллы гына гөрзи ята иде.* А.Тимергалин. *Улының укый башлаган китабы ачык килеш өстәлдә ята.* М.Маликова

6) Махсус урнаштырылмаган, җыелмаган булу; аунау. *Гәзит-журналлар идәндә ята.* Г.Камал. *Лапас астында киселгән, туралган каен утыны ята – беркемнең аны яхшылап өеп куярга кулы җитмәгән.* Н.Фәттах

7) Берәр урында саклану. *Бу китап миндә әле дә саклана. Документлар һәм башка кыйммәтле кәгазьләр белән шкафта ята.* Т.Кәримов. *Рәсем әле дә шкаф тартмасында ята...* Г.Әдһәмова

8) Файдаланылмау, буш тору. *Авыл тирәләрегездә, су буйларыгызда, тау битләрегездә күпме җирләрегез әрәмгә ята.* Т.Гыйззәт. *Ярый әле карчык әбитне кәрзингә салып җибәргән, юкса ул күчне кая куйган булыр идем. Ике умартам буш ята иде, бик шәп булды әле бу.* Ф.Яруллин

9) Күпмедер вакыт дәвамында кайда булса да булу, тору. *[Ул] Өч атна, яңгырга-карга батып, авылда ятты.* А.Гыйләҗев

10) *сөйл.* Яшәү, гомер итү, йөрү. *Ни хәл, ничек ятасыз?* Г.Исхакый. *Чит җирдә, кеше почмагында ни дип ятыйм ди мин, үз йортымнан китеп?* Р.Зарипов

11) *сөйл.* Берәр эш белән мәшгуль булу. *Эштән кайтып, киемнәрне алыштырып, клубка репетициягә җыенып яталар иде кызлар.* М.Мәһдиев. *Анда инде аның биш китабы дөнья күргән, ә тагын алтынчы китабы басмага әзерләнеп ята.* Р.Зәйдулла. *Әкрен генә эшләп ятабыз*

12) Егылу, сөрлегү. *Җил тибрәткән сары җиз башаклар Җиргә яттылар.* М.Җәлил. *Игеннәр җилле яңгырдан соң сөрлеккән, каерылып-каерылып ята.* Ш.Галиев

13) Билгеле бер урынны алып, биләп тору, җәелгән булу. *Якты күл буйлап барып, Шайтан чокыры янынннан үтеп үрне менгәч, Миләүшә елгасы ялт итеп җәелеп ята.* А.Алиш. *Тирә-якта көне буе тургай җыры, Зәңгәр диңгез кебек ята иген кыры.* Г.Латыйп

14) Нинди дә булса юнәлештә сузылып күренү. *Юлдашлар, иелә төшеп, алда сузылып яткан буш, туры юлга карадылар.* А.Гыйләҗев. *Алда, юлны бүлеп яткан елга аръягында, биек тау өстендә, агач стеналар белән әйләндереп алынган Зәй крепосте күренде.* В.Имамов

15) Өслекне каплап алу; китмәү, бетмәү. *Аннары, җил-бураннарын туздырып, кыш килде. Декабрь башларында ук җиргә кар ятты.* М.Садыйков. *1941 елда кар иртә ятты. Шактый икмәк, бигрәк тә солы, бодай кар астында торып калды.* М.Әхмәтҗанов

16) *күч.* Берәр кешенең бурычына, вазифасына керү; йөкләнү, авырлык төшү. *Мәчет имамнарында бәйрәмне оештыру өчен шәхси җаваплылык ята.* Шәһри Казан

17) *күч.* Гадәттә *гүр*, *кабер*, *табут* сүзләре янында килгәндә, «үлү», «вафат булу» мәгънәсен белдерә. *Бу юлы аның янында кыя кебек ире дә, утка керергә әзер торган авылдашлары да юк. Алар инде барысы да салкын кабердә яталар.* Ф.Бәйрәмова. *Әллә кайда, Литва җирендә салкын гүрдә ятасың...* Р.Хәбибуллина

18) *күч. Күңел*, *җан*, *йөрәк*, *колак* сүзләре янында килгәндә, «ошау», «ярау», «ятышлы булу» мәгънәсен белдерә. *Күңелең ята икән, миндә торып калырсың.* В.Имамов. *Һавасы да җанга ятмый чит җирләрнең.* Г.Мөхәммәтшин

19) *күч. Күңел*, *җан*, *йөрәк*, *йөз* сүзләре янында килгәндә, «авыр тойгы, хис биләп алу», «басу», «изү» мәгънәсен белдерә. *Нинди дер сәер нәрсә миен томалады, авыр тойгы булып йөрәгенә ятты.* Т.Галиуллин. *Малайның йөзенә яткан болыт шәүләсен күрү белән, ул үзенең болай дип сорарга тиеш булмавын аңлады.* М.Кәбиров

20) *күч.* Күңелдә, йөрәктә, җанда тирән урнашу, хәтердә саклану. *Ләкин сугыш турында йөрәгендә ятканны әйтер өчен, гади кеше сүзләре генә җитми аңа – бик көчсез алар.* Ә.Еники. *Хан телендәге нахак сүзләрне дә, аның күңелендә яткан мәкерне дә тойды Сәет.* В.Имамов

21) *күч.* Килешле булу, өстә матур күренү. *[Кырык биш-илле яшьләр тирәсендәге хатын-кыз судья] Ыспай гәүдәсенә ятып, килешеп торган, үзенә җитди кыяфәт биргән костюм кигән.* Р.Кәрами

**2.** *ярд. ф. функ.* 1) Төп фигыльдә белдерелгән эш-хәрәкәт яки халәтнең озак дәвам итүен белдерә. *Менә Гөлсем әнисе белән --- икесе генә дөнья көтеп яталар.* А.Әхмәтгалиева

2) Билгеле бер хәлдә яки сыйфатта үзгәрешсез калуны белдерә, шул хәл, сыйфатның дәвамлы саклануын күрсәтә. *Җаектан мине алырга килүче Алты-биш Сапый дигән кеше әле Казанга килеп җитмәгән икән, шул сәбәпле Бәдри абзый белән без бер-ике атна кадәр шул кешене көтеп яттык.* Г.Тукай

3) Эш-хәрәкәтнең хәзерге моментта башкарылуын белдерә яки сизелеп торган сыйфатка даимилек төсмере өсти. *Әнә, безнең күршедә бик әйбәтләп туй итеп яталар.* Әкият. *Менә улыма бирерсез боларны, акчасызлыктан интегеп ятмасын.* Р.Вәлиев

4) Төп фигыльдә белдерелгән аерым бер үзенчәлекле сыйфатта калуга басым ясый. *Синнән башка чит илләрдә каңгырып ятам бит.* Р.Рахман

◊ **Ятып калу** 1) Берәр нәрсәдән мәхрүм булу. *Ятып калганчы, атып кал.* Мәкаль; 2) Сугыш кырында үлеп калу, һәлак булу. *Әтисе сугыш кырында, чехлар җирендә ятып калган, әнисе белән икәү генә яши иде Хәлимә.* В.Нуруллин. **Ятып тору** Ятышлы булу, килешеп тору. **Ятып түшәм санаган** Булдыксыз, юньсез, ялкау кеше турында. *Бар егетнең җебегәне – Ятып түшәм санаганы.* Н.Исәнбәт

**Ята бару** Һәрберсе, бер-бер артлы яту. *[Чәчкечтән төшкән бөртекләр] Йомшак җиргә барып төшкәч, бөтенләй тынып, юашланып калдылар, бер-бер артлы тезелеп-сузылып, җир куенына ята бардылар.* Н.Фәттах

**Ята башлау** Ятарга әзерләнү. *Ярый, шулай вакыт үтте, йокларга ята башладык.* З.Мурсиев

**Ята бирү** Һаман да ятуны дәвам итү. *[Телефон] Хуҗабикәсенә үпкәләп, оешып-бөрешеп, мәче сыман киштәдә ята бирде.* Р.Рахман. *Ярар, әлегә тын гына ята бир.* А.Хәсәнов

**Ята төшү** Бераз, берникадәр яту. *Манук бәк, сөңгесен еракка сузып, алга ята төшкән.* В.Имамов

**Ятып алу** Аз гына, кыска гына вакытка яту. *[Ләйлә] Сыерын савып көтүгә кугач, эшкә киткәнче, бераз ятып ала иде.* Ф.Яруллин

**Ятып бетү** Барысы да яту. *Балалар ятып беткәч, ярты төн авышкач, Гөлсем, ялгыз калып, кухняда кер үтүкләргә тотынды.* Р.Мулланурова

**Ятып тору** Әле, хәзерге вакытта яткан хәлдә булу; вакытлыча, хәзергә, бераз вакытка яту. *Мин арыдым инде, атакай, бераз ятып торам.* М.Әмирханов

**Я́Т-ЧИТ** *с.* **1.** Таныш булмаган, билгесез. *Шушы ят-чит дөньяда*

*әңгәмәдәш табылуына сабыйларча сөенгән Сабирҗан карт тәмам җанланды.* Н.Гыйматдинова

**2.** *и. мәгъ.* Чит кешеләр; чит җирләр. *Ят-читләр күркәм булса да, Үз илем якын икән.* Ф.Яхин

**ЯТЫМ** *с. к.* **ятыш**. *Иҗат шундый: яңалардан яңа Бөек көчләр сорый үзенә; Йөрәкләргә ятым булсын өчен, Тәмлеләрен көтә сүзнең дә.* Җ.Вәлиди

**ЯТЫМЛЫ** *с. к.* **ятышлы**. *Аның башында кыйммәтле каракүл бүрек, өстендә артык ятымлы тегелгән яхшы пальто, аягында американ итек иде.* Г.Ибраһимов. *Ул – күңелгә ятымлы, әйбәт егет.* Ш.Камал

**ЯТЫНКЫ** *с. сөйл.* Авыш, иенке. *Яр буенда ятынкы кәүсәле таллар үскән*

**ЯТЫШ** *с.* **1.** 1) Таман, уңай, уңайлы эшләнгән; килешле булган. *[Мәдинәнең] Иреннән бер ат, бер сыер, дүрт сарык, бәләкәй, шома гына нарат өй һәм шуңа ятыш җыйнак кына такта өйалды, читән абзар һәм ат сарае калган иде.* Ш.Камал

2) Ягымлы, күңелгә хуш килерлек. *Ул картлар белән карчыкларның күңеленә дә бер-ике ятыш сүз әйтеп үтә.* Г.Ибраһимов. *[Нургали] Көеккә килеп җиткәндә генә йомшады, җанга ятыш җылы сүзе чыкты.* Г.Галиева

3) Туры килеп торган, җайлы, уңай булган. *Тегермәнче кызы безнең Фатих байларга бик ятыш кыз иде.* Г.Исхакый. *Минем телем – меңәрләгән ишләре күк, тыйнак тел ул. --- Үзенә җай, үзенә ятыш аның көе: «Сак-Сок»лары, «Рамай»лары, «Сарман»нары, «Гөлҗамал»ы, «Карурман»ы, «Әллүки»е...* Р.Фәйзуллин

4) Берәр эшкә күнеккән, өйрәнгән, ияләнгән. *[Нигъмәтулланың] Эшкә тотынганда ук кулының ятыш, сәләтле икәнлеге күренеп тора.* З.Зәйнуллин

**2.** *рәв. мәгъ.* Туры килеп, тәңгәл булып. *Исеменә ятыш килеп чыкты шул кушаматы да, юкка түгелдер! Кем әйтмешли, исеме җисеменә бигрәк туры килеп тора!* Н.Кәримова

**ЯТЫШЛЫ** *с.* **1.** 1) Килешле, гәүдәгә ятып торган. *Яшь кызларның зифа гәүдәләренә искиткеч ятышлы иде солдат киеме.* Ф.Сафин

2) Ярарлык, уңай, файдалы. *Аныңча, кешегә ошый, аның күңеленә ятышлы әйберләр генә матур һәм гүзәл.* К.Гыйззәтов. *Вакытлы эш эзләүче студентлар җәйнең инде беренче аеннан ук күңелләренә ятышлы, төп таләпләренә туры килерлек шөгыль сайлау белән мәшгуль.* Г.Мәхмүтова

3) Туры килгән, төс булган. *Күлмәккә ятышлы муенса да аласы булыр.* А.Гыйләҗев. *Кызның тавышы да гәүдәсенә, буй-сынына бик ятышлы, искиткеч матур, ягымлы булып ишетелде Хариска.* А.Фәләх

4) Ягымлы, сөйкемле, күңелгә хуш килерлек. *Сөйләшүгә Усман ага да кушыла. Күңелгә ятышлы әңгәмә килеп чыга.* А.Нәҗми. *Бер кичне чит номер шалтыратты да, йомшак, күңелгә ятышлы кызлар тавышы үзен Роза дип таныштырды.* А.Галимов

5) Эшкә күнеккән, гадәтләнгән, оста булган, эш белгән. *Ходайга шөкер, дипломы бар, эшкә ятышлы кулы бар...* Г.Гыйльманов

**2.** *рәв. мәгъ.* 1) Тәртипле, ягымлы итеп. *Аның күңелгә ятышлы сөйләшүе дә, яше белән үзеннән олырак булуы да, килеш-килбәте дә – барысы да Фәһимәне әсир итте.* Д.Каюмова. *Бервакытта да артык сүз сөйләмәс, кычкырып көлмәс, сорауларыңа сабыр гына җавап бирер дә күңелгә бигрәк тә ятышлы итеп елмаеп китеп тә барыр.* Әлмәт таңнары

2) Ошарлык итеп, уңай тәэсир калдырырлык булып. *Шулар арасында Фәһим бабай Идрисов шигырьләре колакка бик ятышлы яңгырый.* Л.Кәшфи. *Кыскасы, бу көнне иртәнге чәй һәркем өчен бик тәмле булды, чәй янында сөйләшү күңелгә ятышлы үтте.* Р.Гариф

3) Эзлеклелек белән, бәйләнешле итеп; туры китереп. *Аның тавышы йомшак, ягымлы, әйткәннәре бер-берсенә бик ятышлы килеп, җанлы гына үрелеп бара.* Г.Бәширов. *Классиклар иҗатын һәр чор үзенчә – заман вазгыятенә бәйле, рухи таләпләргә ятышлы укыган төсле.* Т.Галиуллин

**ЯТЫШЛЫЛЫК** *и.* Ятышлы булу сыйфаты; төзеклек, гармония. *Вакыйгасына, персонажның табигатенә, аның үзенчәлегенә абсолют тәңгәл килгән сүзне эзләп табу таланты, сүзләр арасындагы ятышлылык, әсәр моңы – санап бетерерлекмени соң әсәрдәге әдәби сыйфатны, яңгырашны, сүз тылсымын көчәйткән сыйфатларны!* М.Юныс

**ЯТЫШСЫЗ** *с.* **1.** 1) Йогышсыз, килешеп тормаган, туры килмәгән. *Ботинкалар аның [Вилданның] куе зәңгәр йоннан бәйләнгән спорт костюмына шулкадәр ятышсыз иде, Мәрьям ирексездән көлеп җибәрде.* М.Маликова

2) Күңелгә ятмый торган, ямьсез. *Ләкин кайчандыр сандугачтай сайрап торган гармуннан бу юлы ятышсыз, кызганыч тавышлар гына чыга иде.* Г.Әпсәләмов

**2.** *рәв. мәгъ.* Урынсыз итеп, тиешсез рәвештә, кирәкмәгәнчә. *Ул шулай, капыл гына ятышсыз сорап куюыннан аптырап, озын нечкә бармаклары белән пиджәк төймәсен боргалады.* А.Вергазов

**ЯТЫШУ** *ф.* Килешү, туры килү, урынлы булу. *Аның гәүдәсенә, йөзенә, мул кашларына – тыныч, салмак табигате; ашыкмыйча, сүз кадерен белгән бай, образлы сөйләме – холкына ятышып, табигатьтә гармония, илаһи иплелек барлыкка ышандырып тора.* Т.Галиуллин

**Ятышып җитү** Ахыргача, тулысынча ятышу. *Бу нәрсә аның тыйнаклыгы, канәгатьчәнлеге белән һәм шулай ук лирик җырларындагы сентиментальлек нечкәлеге, моңга бирелүчәнлек сызыгы белән ничектер бик үк ятышып җитми шикелле.* Н.Исәнбәт

**Ятышып тору** Әле, хәзерге вакытта ятышлы күренү. *Аның өстендә кыска җиңле аксыл кофта һәм көрән итәк: болары да, иясен һаман да картайтырга теләмәгәндәй, теге килешле гәүдәгә ятышып тора.* Г.Шакиров

**ЯТЬМӘ** *и.* 1) Балык, кош, җәнлек аулау өчен челтәрләп үреп эшләнгән махсус җайланма; ау. *Икегә бүленгән ирләрнең бер өлеше алдан зур күсәкләр белән шапы-шопы китереп су өстен кыйнап барды, калган ирләр ятьмә өстерәде.* В.Имамов. *Ике сунарчы, чаналарыннан төшеп, ятьмә җәяләр – [бүре баласы] Чатан өстенә ыргытмакчылар.* А.Хәсәнов

2) Әйбер тутырып йөртү өчен, җептән, баудан, тимерчыбыктан үреп эшләнгән җайланма. *Ханым грушалар тутырылган ятьмә күтәреп бара.* М.Хуҗин

3) *махс.* Дошман күзеннән яшерү, маскировка өчен эшләнгән җайланма. *Ул [олырак яшьләрдәге солдат] бүреген артка этеп, мыекларын сыпырып алды, өстенә маскировка өчен ятьмә корылган авыр тупка күз төшерде.* Г.Әпсәләмов

4) *күч.* Пәрәвез. *Көн-төн корды үрмәкүч ятьмәсен, Посып кына күзәтте кем эләгәсен.* Р.Шәрипова

5) *күч.* Тозак, капкын, астыртын корылган хәйлә. *Тол хатын кешене гайбәт ятьмәсенә эләктерүләре, исемен пычратулары мөмкин.* Ш.Камал. *Гөлҗиһан*

*алар түгел, Гөлҗиһан – аерым: аның бервүгә дә аяк чалганы яисә хәйлә-мәкер ятьмәсе үргәне юк!* Н.Гыйматдинова

6) *күч.* Тонык һәм сыек кына томанланып күренгән нәрсә; өртү. [*Камали] Юлдашының офык сызыгындагы төтенле ятьмә аша җемелдәгән кояшка борчылып караган күгелҗем күзләрендә сүрән тоныклык күреп, юаткан сыман әйтте...* К.Нәҗми

◊ **Ятьмә кору** Берәр кешегә карата начар уй, начар максат белән астыртын эш планлаштыру, эш-гамәлләренә тоткарлык ясау. *Тантана итә башлагач, төрек сәрдарларының нинди мәкерле ятьмә корып куюын да шәйләп, абайлап өлгермәде алар [мадьяр җайдаклары].* В.Имамов. **Ятьмә салу** *к.* **ятьмә кору**. *Аумакай гавамның тозак әзерләвен, ятьмә салуын, корбан итеп сине сайлавын тоеп яшисең.* Көмеш кыңгырау

**ЯТЬМӘЛЕ** *с.* 1) Ятьмә салынган, ятьмәсе булган. *Балык та каргыйдыр елгасын – Ятьмәле, елымлы дөньясын...* Г.Афзал

2) Җептән, баудан, тимерчыбыктан үреп ясалган. *Баш-башында ятьмәле футбол капкасы булган зур спорт мәйданы гөж килеп тора.* Р.Кәрами

**ЯТЬМӘ ЯТАК** *и.* Ятып ял итү өчен, баудан үреп ясалган асылмалы ятак; гамак. *Баудан үреп ясаган ятьмә ятакта бер кызчык җырлый-җырлый тирбәлә.* Җ.Тәрҗеманов

**Я́У** I *и.* 1) Дошман. *Яу юк, димә – яр астында, бүре юк, димә – бүрек астында.* Мәкаль. *Аннан соң углы Атсыз хан атасы урынына утырып, берничә еллар яуны җиңеп, ауны аулап, атасы артыннан мәңгелек йортка китте.* Шәҗәрәи төрек

2) Һөҗүм итеп килгән күпсанлы гаскәр. *Карт баһадирның үлемен ишеткән дошманнар тиз үк колакларын торгызганнар, һәм Болгар иленә яу килгән.* А.Гыйләҗев. *– Кайтуга ук, мин Хаҗитархан өстенә зур яу белән чабам, аны үземнең олысыма әйләндермичә тукталачак түгел! – дип ярсыды Мөхәммәдгәрәй, тезгенен үз көенә селкеп.* В.Имамов

3) Сугыш, коралллы бәрелеш. *Яу юкта батыр күп.* Мәкаль. *Яудан яраланып кайткан әтиләре ята-тора ике ел яшәгән дә дөнья куйган.* С.Сөләйманова

4) *күч.* Күп булып, берьюлы зур агым булып килә торган нәрсә; ташкын. *Монда, җаный, буран. Көрт яу булып таудан сикергән.* А.Хәлим. *Ирексездән, университетны абитуриентлар явы басып алган икән, дип уйлыйсың.* Татарстан яшьләре

**Я́У** II *и.* 1) *бор.* Эч мае. *«Хөсрәү вә Ширин»дә [шундый юллар бар]: --- ләкин җәү сүндерә, ташса уҗаудан, ягъни борынгы яктырткычның эч мае – яу салына торган савыты уҗау дип аталган.* Р.Әхмәтьянов

2) *Күз* сүзе белән берлектә: күзне ачып-йомып, алмасын кибүдән саклаган дым // Күздәге чагылыш, күз нуры. *Тукучының күз явы паласка сеңә, ахрысы.* Р.Батулла. *Ул күзләрнең явы котылгысыз: хәтта үпкәләп читкә борылып бассаң да, син Әлфинәнең җете карашын тоеп торасың.* К.Кәримов

**Я́УБАШЫ** *и. хәрби тар.* Гаскәр башлыгы, сәргаскәр. *Аксакаллар, көрәк кадәр ак сакалларын җиргә кадәр тидерә-тидерә, гуннар яубашы Атиллага рәхмәт укыдылар.* М.Хәбибуллин

**ЯУГИР** *и. хәрби тар.* Каһарман, батыр сугышчы, баһадир. *Борынгы Рим амулетларында һәм геммаларында сугыш киеме кигән яугир – Абраксас илаһ рәвешендә сурәтләнә.* А.Тимергалин

**ЯУДАШ** *и.* **1.** Кем беләндер бер яуда бергә булган кеше; көрәштәш. *Ә тәүге һөҗүмнәр әле дә күз алдымда, күпме яудаш-коралдаш һәлак булды.* К.Латыйп

**2.** *с. мәгъ.* Бер яуда катнашкан. *Байтак вакыт, амбразураны гәүдәсе белән каплап, яудаш иптәшләренә алга бару форсатын биргән батырлыкны Матросов беренче булып эшләгән, дигән ышаныч яшәп килде.* Кызыл таң

**ЯУДЫРУ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **яву**. *Кырык елдан соң Аллаһы Тәгалә янә кырык ел яңгыр яудырыр, һәм кешеләр үләннәр кебек үсеп чыгарлар.* А.Хафиз

2) Берьюлы күпләп ату, ташлау, юнәлдерү. *Ике яклап тау башыннан ук таш яудыру өчен иң-иң кулай урын...* В.Имамов. *Аннан – өстән торып, безнең ыру өстенә ни дип ләгънәт яудыралар?* А.Хәсәнов

3) Күп итеп бирү, мулдан китерү. *Ул [акчаны] бер дә кызганмый инде, никадәр теләсәң, шулкадәр яудыра.* Г.Камал. *Юмарт кояш җылы нурларын җир өстенә мулдан яудыра.* Безнең гәҗит

**Яудыра бару** Торган саен күбрәк яудыру. *Ләкин Газинур, картның салкын карашын гүя сизмәгән кебек, үзенең яңадан-яңа сорауларын яудыра барды.* Г.Әпсәләмов

**Яудыра башлау** Яудырырга тотыну. *Госпитальгә хат артыннан хат яудыра башладым.* И.Гази

**Яудыра бирү** Һаман яудыру, яудыруны дәвам итү. *[Галимҗан] Зарф хәлфәгә җае чыккан саен, һәр форсаттан файдаланып, сорауны яудыра бирде.* С.Поварисов

**Яудырып алу** Бераз, берникадәр яудыру. *Бераз «матур» сүзләрен яудырып алганнан соң: – Борчылма, мин сиңа ярдәм итәрмен, – дип тынычландырды.* Шәһри Казан

**Яудырып бетерү** Яудыруны тәгәлләү; ахырга кадәр яудыру. *Дала яугирләре, Тимер-Мөэмин гаскәре өстенә ук яңгыры яудырып бетерүгә, җиде-сигез кисәккә бүленделәр.* В.Имамов

**Яудырып тору** Бертуктаусыз яудыру. *Аларның сорауларын көтмичә үк, сүз артыннан сүзне яудырып торды, ди, җитез егет.* А.Алиш. *Рамил [әбисенә] сорау арты сорау яудырып тора.* А.Әхмәтгалиева

**ЯУЛА́У** *ф.* 1) Көч белән буйсындыру, сугышып басып алу. *Заманының техник казанышларына ия булмасаң, кылыч болгап кына таш диварлы кальгаларны яулап булмый...* Р.Зәйдулла

2) *күч.* Нәрсәгә дә булса ирешү, казану. *Бала күңелен, мәхәббәтен һәм хөрмәтен бары тик игелекле гамәлләр белән генә яулап була.* А.Йосыпова. *Нәкъ шушы сыйфатлары белән ул төрле кыйтгаларда яшәүче кешеләрнең ихтирамын яулый һәм кырыс шартларда да исән кала.* Н.Ганиев

3) *күч.* Биләү, үзенә җәлеп итү, чолгап алу. *Бала күңелен яулардай заманча китаплар күбрәк булган саен, сабыйлар да туган телләрен кечкенәдән үк яхшы үзләштерә алырлар.* К.Фәтхуллова

◊ **Яулап алу** Тырышып, авырлык белән ирешү, казану. *Балаларын зур тормыш юлына озатканда, аталар болай диләр: «Мин сиңа фамилиямне бирдем, исемне үзең яулап ал».* М.Маликова. *Барыбыз бергә оешып, бөтен көчне бер йодрыкка туплап эш итсәк, җиңү яулап алу җиңелрәк булыр иде.* Т.Нәбиуллин

**Яулап алу** Тулысынча яулау. *Син, колак ишетмәгән каһарманлыклар күрсәтеп, берүзең скиф һәм герман патшалыкларын яулап алдың.* С.Шәмси

**Яулап бетерү** Барысын да яулау; тулысынча яулау. *Ул [Чыңгыз хан] үзе һәм аның варислары бөтен Шәрыкны яулап бетерә яза, Европаның да шактый өлешен буйсындыра.* Р.Фәхретдинов

**Яулап килү** Электән үк, һәрвакыт, гел яулау. *Мин ярышларда һәрвакыт алдынгы урыннарны яулап киләм.* Аманулла

**Яулап тору** Һәрвакыт, даими яулау. *Китапханә республикада игълан ителгән барлык конкурсларда призлы урыннар яулап тора.* Кызыл таң

**Яулый бару** Бер-бер артлы яулау; торган саен күбрәк яулау. *Тамашачы мәхәббәтен көннән-көн яулый бара, алкышларның да чиге юк төсле тоелды.* А.Шәймәрданов

**Яулый башлау** Яуларга керешү. *Инде савромат-сармат халкының барлыкка килүен, үсүен, күчәеп китеп, яңа җирләр яулый башлавын күздән кичерик.* С.Шәмси

**ЯУЛАШУ** *ф.* 1) *урт. юн. к.* **яулау**. *Каулы җиргә ут салып, Утны кайдан утларсың? Халык белән яулашып, Яхшыны кайдан табарсың?* Дастан. *Казан ханлыгын яулашып биргәннәр дә, Мәскәү тирәли меңләгән чиркәүләр төзешеп, гөмбәзләрен таланган Казан алтыны белән япканнар.* М.Галиев

2) Даулау, көрәшү. *Зирәк Тукай шигъри сөңгесе белән иреккә юл яулашып үлемсезлеккә кергән.* Р.Зарипова

**ЯУЛЫК** *и.* 1) Башка бөркәнә торган кием-салымның бер төре: төрле формадагы тукыма кисәге. *Баш яулыкларының төрләре һәм атамалары байтак: акча яулык (ак яулык); дарай яулык – парчалы ефәк яулык; куш яулык – зур яулык, аны иргә чыккан хатыннар бәйләп йөргән; кыекча яулык (өчпочмаклы яулык); кычыткан яулык – кытай кычытканыннан сугылган яулык һ.б.* А.Тимергалин. *Кеше арасына чыкканда гына кияргә тоткан кара җирлеккә кызыл розалар төшкән матур күлмәген киде, башына алмалы француз яулыгын алып бәйләде.* А.Хәйретдинова

2) Борын, бит-кул сөртү өчен әзерләнгән һәм һәрвакыт янда йөртелә торган кечерәк тукыма кисәге. *Яулык, димәк, әүвәле ашаганнан соң кул сөртү өчен кулланылган йаглык булып чыга (сөлге, тастымал, кульяулык). Шуннан соң башъяулык (баш яулыгы), борын яулыгы, бит яулыгы сүзләре барлыкка килгәнгә охшый.* А.Тимергалин. *Әтием хаҗга баргач, алтын алкалар миңа китергән иде, алар кул яулыгына бәйләгән, сандык почмагында.* В.Ильясов

**ЯУЛЫКЛЫ** *с.* **1.** Яулыгы булган, яулык бәйләгән, яулык бөркәнгән. *Ачык йөзле, ак яулыклы тыйнак татар әбиләре!* Р.Габделхакова

**2.** *и. мәгъ.* Яулык бөркәнгән яки дини кагыйдәләр нигезендә яланбаш йөрми торган хатын-кыз. *Нәрсә генә дисәң дә, барыбер сәер бу – яулыклы...* Г.Гыйльманов. *Бөтен дөнья күләмендә исламга пычрак ату, террорчы ярлыгы тагу, һәр яулыклыга яки чалма-чапан, кәләпүшлегә шикләнеп карау вазгыятендә безнең мөфтияткә дә җиңел булмагандыр.* Ислам

**ЯУЛЫКЛЫК** *и.* **1.** 1) Яулык өчен махсус эшләнгән тукыма. *Чите каймалы яулыклык*

2) Бер яулыкка җитәрлек тукыма кисәге. *Юк, син миңа менә шушы кызыл комачтан бер яулыклык кына кис.* А.Гыйләҗев

**2.** *с. мәгъ.* Яулык ясарга яраклы; бер яулыкка җитәрлек. *Әсмабикә бик гаҗәпсенеп, тәэсирләнеп, карчыкка яулыклык комач үлчәде, гадәтенчә, ситсыны чытырдатып тартып та китермәде, ул сораганнан мулрак кисте.* А.Гыйләҗев

**ЯУЛЫКЧАН** *рәв.* Яулык бәйләгән килеш. *Беренче күренгәндә Кәшифә яулыкчан иде.* Сөембикә

**ЯУРЫН** *и.* 1) Арканың өске – муен, иңбашлар һәм калак сөякләре арасындагы өлеше

2) Кием якасының шул турысы. *– Яурыннары каймалы, Төймә бавы тартмалы Ал кара кеш тун бирим. Бу тунымны ки, – диде [Идегәй].* Дастан

3) *күч.* Арткы як, арка. *Автобус тәрәзәләрендә, койрыкка койрык, яурынга яурын тәңгәл килеп, Европаның кысан тигезлекләреннән Азиянең иркен далаларына, Азиянең иркен далаларыннан Европаның кысан тигезлекләренә таба, ялларында ут ташыган ат-аргамаклар ташкыны сыман, тау-калкулыкларның өзлексез чылбыры чаба.* А.Хәлим

◊ **Яурыны киң** Көчле, чыдам, түземле

**ЯУЧЫ** I *и.* Егеткә кыз димләп йөрүче кеше, димче. *Соңыннан Хәмитем яучы җибәрде, илле елдан артык тигез мәхәббәттә гомер иттек.* А.Мансуров. *Егетләр яучы артыннан яучы җибәрә башлыйлар, ә Алтынчәч беркемгә дә карамый.* А.Гадел

**ЯУЧЫ** II *и. к.* **яугир**. *Байтак кына әреп-талаштан соң нугай бәге Йосыф җәйләвенә яучы җибәрделәр.* В.Имамов

**ЯУЧЫЛА́У** *ф.* 1) Кыз сорау өчен яучы җибәрү. *Бервакыт мулла, хаҗга китеп барган чакта, бер ятим кызны күрә һәм үзенә яучылый.* М.Гали. *Әниләр яучыладылар миңа аны.* А.Нәҗми // Димләү. *Ничек килешкәннәрдер: ул үзе мине сорап килгәнме, әллә әтием үзе яучылап биргәнме – анысы миңа мәгълүм түгел.* Г.Галиева

2) Яучы булып бару; димчелек итү. *Абыстай килгән безгә, Кызыбызны яучылап.* И.Юзеев

**Яучылап йөрү** Озаклап яучылау; хәзерге вакытта яучылау. *Мөхәммәд Шакир мулла Чишмәлектән Хасбетдиннең тол калган хатынын яучылап йөри икән.* Р.Батулла. *Кечке уен була торган җиргә якынлашкач – Фәһимәне яучылап йөрүен, чикләвек куакларына җиткәч, Сараны үзенә чыгарга бик авырлык белән күндерүен исенә төшерде.* Р.Кәрами

**Яучылый башлау** Яучыларга тотыну. *Зәйнәпне яучылый башлагач, кыз, үзе белән пәйгамбәр никахлашмакчы була, дип уйлаган һәм ризалыгын биргән.* А.Тимергалин

**ЯУЧЫЛЫК** *и.* Яучы булу; яучы вазифасы; димчелек. *Бу карчыкны, яучылык белән көн күрә, диләр.* М.Хәсәнов. *Яучылык хезмәте татарларда электән үк камилләшкән бер йола булган.* Р.Батулла

**ЯУЧЫЛЫ́К ИТҮ** *ф.* Яучы вазифасын үтәү, яучы булу; димчелек итү. *Кайбер хатыннар хәрам нәрсәләр саталар, ирләр белән хатыннар арасында яучылык итәләр, урамнарда ирләрне аулап йөриләр.* Р.Фәхретдин

**ЯУЧЫЛЫ́К КЫЛУ** *ф. к.* **яучылык итү**. *Менә шуңардан курыкты да Фәрит хәзрәт Нури картның кызы Гөлбануны Закирга алу өчен яучылык кылды.* Г.Ибраһимов

**ЯУШАН** *и. бот.* Бака яфрагычалар семьялыгыннан булган вак кына чәчәкле үлән үсемлек, кайбер төрләре бүлмә гөле итеп тә үстерелә; *русчасы*: **вероника**. *Ландышлар да, левкойлар да, яушаннар да күп үсә.* Ә.Ерикәй. *Яушан (вероника), карабаш (черноголовка) үләннәре безнең кибеттә сатыла.* Шәһри Казан

**ЯФРАГАШАР** *и. зоол.* Яфрагашарчалар семьялыгыннан булган ачык төстәге тышча белән капланган коңгыз; *русчасы:* **радужница**

**ЯФРАК** *и.* **1.** 1) Үсемлекләрдә: һава белән туклану һәм фотосинтез өчен хезмәт итә торган яшел төстә һәм төрле формалы юка пластинка. *Кыярлар, кабаклар да яфрак чыгарып үсә башладылар.* А.Алиш. *Бакчаларда кошлар*

*сайравы, агачларның яфрак ярып чәчәк аткан чаклары җитте.* А.Нәҗми

2) Нинди дә булса үсемлекнең дару ясауда, аш тәмләткеч итеп һ.б. максатлар өчен шул килеш яки киптереп, яки башкача эшкәртеп файдаланыла торган шундый өлеше. *Ашка яфрак салырга онытма*

3) Кайбер ботаника, анатомия һәм зоология терминнарының состав өлеше, компоненты. *Әкмәлнең кайнарланып киңәйгән алсу борын яфрагына эләгеп торган тир бөртекләре дерелдәп киттеләр.* А.Гыйләҗев. *Сәламәт кулы белән колак яфрагын тотып, беркавым уйланып тора.* В.Нуруллин. *Үги ана яфрагы үләне үсә.* А.Нәҗми

**2.** *с. мәгъ.* Нинди дә булса үсемлекләрнең яфрагыннан (*1 мәгъ.*) ясалган. *Бабай икенче тапкыр чылемен яфрак тәмәке тутырды, чакма таш сугып яндырды, куе төтен таратып тартырга тотынды.* Г.Ибраһимов. *Бәрәңге боламыгы ашап, яфрак чәй эчеп яшәде.* М.Мәһдиев

◊ **Яфрак астына керү** Яшеренү. *[Әхмәтсафа агай], үзенең эшләре чуаласын белеп, барлык эшләрне, һәммә акчасын хаҗи әфәндегә тапшырып, Мәкәрҗәдән сызды, ягъни яфрак астына керде.* Ш.Мөхәммәдев

**ЯФРА́К БӘЙРӘМЕ** *и. этн.* Христианнарда Изге рухның апостолларга күренү хөрмәтенә үткәрелә торган дини бәйрәм; тройчын. *Күп кенә керәшен авылларында аның Яфрак бәйрәме итеп үткәрү йоласы буларак саклануы да язны озатып, җәйне каршылау көне булуына ишарәли.* Н.Максимов

**ЯФРА́К БЕТЕ** *и. зоол.* Гөблә; *русчасы:* **тля**. *Яфрак бете белән шөпшәләр ярдәмендә көрәшәләр.* Кызыл таң

**ЯФРАКЛАНУ** *ф.* Яфрак яру, яфраклар чыгару. *Болыннар яшелләнәчәк, агачлар яфракланачак, чәчәкләр ачылачак.* Й.Акчура. *Кояшның җылыткан җылысы никадәр ихластан булса да, агачларны яфракландырырга, гөлләрне чәчәкләндерергә көче җитмәгәнгәме, --- бу көннәрнең җылысын карчыклар җылысына, бу көннәрнең матурлыгын карчыклар гүзәллегенә охшатканнар.* Г.Исхакый

**Яфраклана бару** Акрынлап яфраклану. *Агачлар яфраклана бара*

**Яфраклана башлау** Яфракланырга тотыну. *Урманнар яфраклана башлаган*

**Яфраклана төшү** Берникадәр яфраклану. *Куак яфраклана төшкән*

**Яфракланып килү** Соңгы арада яфраклану. *Хәзер урман яфракланып килә*

**Яфракланып китү** Кинәт яфраклану. *Куакларның яфракланып киткәнен сизми дә калдык*

**ЯФРАКЛЫ** *с.* 1) Яфрагы яки яфраклары булган. *Бу моңсулыкка нокта куярга вакыт иде: тирә-юньдә зөбәрҗәт яфраклы урман лабаса!* С.Гаффарова

2) *махс.* Ылыслы урманга каршы буларак яфрак яра торган; шундый агачлар үскән. *Биом – билгеле бер җирлектә: тундрада, яфраклы урман, дала, тропик урманнар, саванна һ.б. урыннарда таралган тере организмнар (хайваннар, үсемлекләр, гөмбәләр һәм микроорганизмнар) җыелмасы ул.* Биология

**ЯФРАКЧА** *и.* 1) Кечкенә яфрак. *Язларда минем күңел дә Яфракча. Нәкъ шул яфракча Яшәрмәсен дә белә, Очып каласы килә...* С.Якупова

2) *бот.* Клевер, акация кебек үсемлекләрдә катлаулы яфракларның бер өлеше

**Я́ХТА** *и. нем.* Спорт яки туристлык максатларында куллану өчен моторлы яки җилкәнле кечкенә судно. *Култыкка караган бер яклы урамы аеруча ямьле – аның икенче ягын ярга бәйләп куелган шхуна, баркас, яхта, катер, көймәләр тәшкил итә.* Т.Әйди. *Бик күпләр – гаражларында «ланд крузер», причалларында яхта торганнар да, бу яктан караганда, ярлы-ябагайлардыр, мөгаен.* Н.Шәрифуллин

**Я́ХТАЧЫ** *и.* Яхтада йөрүче спортчы. *Алиев исемле бер яхтачы егет үзенең иптәшләре белән Төркиягә киләчәк икән.* И.Надиров. *Анда Ульяновск, Таллин, Мәскәү, Самара һәм Россия белән Татарстанның башка шәһәрләреннән унсигез яхтачы катнашты.* Кама ягы

**ЯХТ-КЛУБ** *и. рус* 1) Су спортының яхталар белән шөгыльләнүче спортчыларны берләштерә торган спорт оешмасы. *Казансу елгасы буйлап су таксие, елга трамвайлары йөреячәк, яхт-клуб булдырырга да җыеналар.* Мәйдан. *Биредә ел әйләнәсендә эшли торган яхт-клуб, техник спорт үзәге, мунчалар комплексы, агротуристик ферма, тәрәзәләре Иделгә карый торган 65 номерлы кунакханә булыр дип көтелә.* Әлки хәбәрләре

2) Шундый оешма һәм аның су станциясе урнашкан бина. *Ярымутрауларның беренчесендә – яшәү «кыры», икенчесендә «Ривьера» күңел ачу комплексының дәвамы, ресторан комплексы, яхт-клуб, тукталу урыны, парк зонасы төзеләчәк дип планлаштырыла.* Шәһри Казан. *Мондый зур елга коену урыны гына түгел, ә яхт-клуб өчен менә дигән урын да.* Таң

**ЯХТКЛУБЧЫ** *и.* Яхт-клуб әгъзасы. *Ул – яхтклубчы*

**ЯХУТ** *терк. фар. иск.* Яки, яисә. *Я Ходай, фәрештәме керә... яхут бүлмәмә күктән илаһи нур капусымы ачыла...* Г.Ибраһимов. *Шулай итеп, Җиһанша хәзрәт берничә еллар халыкның малыны вә ашыны яхут башыны рәхәт-рәхәт ашады исә дә, бәгъзы вакытларда бугазына аркылы китерүчеләр дә булды.* З.Һади

**ЯХШАТЛАНУ** *ф.* Кем алдындадыр икейөзлелек күрсәтү, ялагайланып, үзен яхшы итеп күрсәтергә тырышу. *Хуҗа урыныннан кузгалып өлгергәнче, Мөхәммәтнең әтисе, үзе ярдәм сорап барачак җитәкчегә яхшатланыпмы, җәһәт кенә мотор янына килде дә бауны уң кулына урады.* З.Хөснияр. *Шуны тоеп, күреп утырган Валериан Куйбышев (аның әле соңгы араларда гына Үзәк Комитет секретаре итеп сайланган чагы), Генераль секретарь алдында яхшатланып, ораторны бүлдерергә форсат тапты.* Р.Мөхәммәдиев

**Яхшатлана башлау** Яхшатланырга тотыну

**Яхшатланып йөрү** Озак вакыт яхшатлану; хәзерге вакытта яхшатлану. *Аннары безгә яхшатланып йөрдең.* М.Маликова

**Яхшатланып тору** Гел, һәрвакыт яхшатлану; әледән-әле яхшатлану; хәзер, әле яхшатлану. *Син дә яхшатланып тормасана!* Л.Лерон

**ЯХШАТЛЫ** *с.* Абруйлы, авторитетлы, дәрәҗәле. *Иясез песиләрне, хуҗасыз этләрне иркәләп, balаң алдында яхшатлы булып йөрү җиңел ич ул!..* А.Гыйләҗев. *Әтисе белән әнисе икесе бергәләп тә, Фәләхкә яхшатлы булырга теләп, бер-берләреннән яшереп тә, ул җәйге һәм кышкы каникулларга кайткан чакларда кулына биреп тә җибәрәләр, перевод белән дә ай саен диярлек салып торалар иде.* В.Нуруллин

**ЯХШАТЛЫЛЫК** *и.* Яхшатлы булу сыйфаты

**ЯХШЫ** *с.* **1.** 1) Уңай сыйфатлары, уңай яклары булган; *киресе*: **начар**. *Гөлсем, кайбер хатыннар кебек, яхшы фатир, затлы киемнәр таләп итеп, беркайчан да аның якасыннан алмый.* С.Поварисов. *Авылның иң уңган*

*хатыннары булган әлеге толларның күбесе, иркен, яхшы йорт күрмичә, салам түбәле нигезләреннән мәңгелек йортларына күчтеләр.* И.Нәбиуллина

2) Тиешле дәрәҗәдәге, югары сыйфатлы, куйган таләпләргә тулысынча җавап бирә торган (сәнгать әсәрләре тур.). *Ыгы-зыгылар узар, постлар онытылыр, яхшы җыр, яхшы шигырь, поэмалар калыр.* И.Юзеев. *Әгәр яңа яхшы әсәр яза алмый икән, иҗатчы үлә, ул тере мәеткә әверелә.* М.Кәбиров

3) Уңышлы, файдалы; уңай тәэсир калдыра торган. *Ул бу җәйне бар гомерен әдәбият укып вә һәртөрле зыялы вә фикерле адәмнәр илә сөйләшеп үткәрү сәбәпле, Зәки бик яхшы фикер хасил итте.* Г.Ибраһимов. *Ул бу юлы да җикеренеп, ачуланып түгел, бик якын кешесенә яхшы киңәш биргәндәй әйтте.* З.Хөснияр. *Рәмзия Рим кызы – укучылары өчен тирән белемле укытучы гына түгел, ул барыннан да бигрәк сизгер күңелле, барысына да бердәй яхшы мөнәсәбәтле кеше дә.* Биектау хәбәрләре

4) Уңай бәяләнә торган, әйбәт; тәрәкле, тиешле дип саналган. *Мин бары тик шуны гына әйтә алам: барлык эшләремне дә, үземчә яхшы ният белән, кешеләргә кулымнан килгәнчә изгелек итү максаты белән эшләдем.* В.Нуруллин. *Өйләнү – яхшы гадәт.* Ш.Галиев

5) Тәҗрибәле, оста, маһир. *Галия ул шундый:囗эштә яхшы коммунист, яхшы эшче, ә кирәк вакытта ул, үзенең кызлыгы белән, ирләрнең гакылларын томалый ала.* Һ.Такташ. *Яхшы тимерче бармагын чүкечкә кыстырмый.* Р.Низамиев

6) Намуслы, кешелекле. *Командир киткәч, Верещагин Урмановка: – Яхшы кеше булса кирәк, – диде.* Г.Әпсәләмов. *Беренче күрүеннән үк сәерәккә санаган бу егет аңа яхшы кеше булып тоелды.* К.Тимбикова

7) Тәртипле, тәрбияле (бала тур.). *Элек яхшы малай булып танылган Кадыйр иптәшләре алдына карак булып басачак.* А.Алиш

8) Бер-берсенә әйбәт, уңай, якын мөнәсәбәттәге, белеш-таныш булган. *[Гөлзифа:] Мин аңлап бетермәдем: сез Айрат Данилович белән яхшы танышлар, ахрысы?* Х.Ширмән

9) Югары әхлаклы, яманаты чыкмаган. *Яхшы гаиләдә тәрбияләндем мин.* А.Нәҗми

10) Затлы, кыйммәтле; каралган, яңа кебек. *Аларның [фаэтоннарның] барсына да яхшы киемле байлар утырган иде.* С.Җәлал. *Өстендә яхшы тун, башында кырма бүрек – танырлык та түгел.* К.Кара

11) Югары сортлы, югары сыйфатлы (азык-төлек тур.). *Мортаза бай кунакларга унар сум акча, берәр киемлек тукыма, остабикәләренә берәр күлмәклек һәм берәр кадак яхшы чәй бүләк итте.* М.Галәү. *«Яхшы пылау казанга яхшы сарык ите, яхшы кишер, яхшы дөге салганда гына була...» – дигән фикерне алга сөрде.* Шәһри Казан

12) *сөйл.* Зур, күп, мул; өмет ителгән кадәр. *Игенче, яхшы уңыш алыр өчен, җирне ашлый.* Т.Әйди. *Жюри картинага яхшы бәя бирде.* М.Маликова

**2.** *и. мәгъ* 1) Яхшылык, уңай як, төрле уңайлык, уңай хәл. *Кеше заманы белән, заманының идеаллары, эшләре белән яши, һәрвакыт яхшыга омтыла.* Г.Әпсәләмов. *Имтиханнар башлангач, ташларга кирәк бу хәтәр уенны, яхшыга алып бармас, дип йөрсә дә, асылда Фәләхнең эшләр киресенчәгә әверелеп китте.* В.Нуруллин

2) Җайлы, уңайлы, әйбәт, канәгатьләндерерлек нәрсә. *Туктының яхшысы асылган, куырдак ясалган иде.* Г.Ибраһимов

3) Әйбәт, уңай сыйфатларга ия булган кеше. *Әле дә ярый, сак кешеләр бар, гаделләр бар, яхшылар күп!..* А.Гыйләҗев. *Яман кыла башласаң, яхшылар болгап атачак.* Р.Батулла

**3.** *рәв. мәгъ.* 1) *к.* **якыннан**. *Ут караңгы, әмма дала егетенең күзләре әле яхшы күрә.* Г.Әпсәләмов

2) Әйбәт, кирәгенчә, тиешле дәрәҗәдә, яхшылап. *Ленаны Әнәс яхшы белә, күргәне дә бар.* А.Гыйләҗев. *Моннан бар тирә-як бик яхшы күренә иде.* А.Хәлим. *Мәктәптә яхшы укыган Рамил, унынчыны тәмамлагач, хәрби училищега керде, аннан инде лейтенант дәрәҗәсендә хәрби хезмәтен башлаган егетне язмыш аз җирләр гиздермәде.* А.Хәйретдинова

3) Нык кына, байтак, шактый дәрәҗәдә. *Бүген, безнең чиккә якынлашу шатлыгыбызны уртаклашкандай, кояш та яхшы кыздыра.* М.Яһудин

**4.** *мод. сүз* Сөйләшеп утырганда әңгәмәдәшнең сүзләре, фикере белән килешүне, ризалашуны белдерү өчен кулланыла; ярый, я, ярар, хуп. *Яхшы, эшләрем бетүгә сугылып чыгармын.* А.Мансуров

◊ **Яхшы күз белән карау** Яхшы фикердә булу, яхшы мөнәсәбәттә булу, ярату, үз итү. *Абзасы аларга яхшы күз белән караса, яшәве дәрәҗәләрәк булыр.* Н.Фәттах. **Яхшы чакта** 1) Ул-бу булганчы. *Яхшы чакта, ал битеңә сары пәрәвез сыман җыерчыклар сарганчы китеп котыл син, Фаягөл аппак.* А.Гыйләҗев; 2) Берәр нәрсә эшләгәнче, усаллыкка киткәнче. *Шук малайларга, бу гадәтләрен яхшы чакта ташларга чакырып, еш кына кайнар сүзләр дә сөйләп алам.* А.Хәсәнов. **Яхшыдан яман туган (нәрсә)** *тирг.* Ачулану, сүгү сүзе. *Беркөнне Сафый карт керде дә, ярлы тәкәббер, дип, яхшыдан яман туган, дип, мине әти алдында әрли башлады.* Г.Ибраһимов

**ЯХШЫЛАНУ** *ф. диал.* Яхшыру, әйбәтләнү, рәтләнү. *Тормышлар да, бик акрынлык белән булса да, яхшыланып маташа төсле.* Н.Шәрифуллин. *Аның күңеле күтәрелеп, йөзе ачылып, хәле яхшыланып китте.* С.Поварисов

**Яхшылана бару** Аз-азлап, акрынлап яхшылану. *Күңелең дөреслеккә тугры икән, адәми зат төзәлә, яхшылана бара.* М.Галиев

**Яхшылана төшү** Бераз яхшылану; тагын да яхшылану. *Икенче елны укыту да җиңеләя, яшәү дә яхшылана төште.* Ф.Зыятдинов

**Яхшыланып китү** Берәр нәрсәдән соң яхшылану; соңгы вакытта яхшылану. *Мулла Габделбарига тәкъдим иткәч, һич кичектергесез кабул итеп, тамга җыйдырып, мөәззин билгеләгән, хәлләре яхшыланып киткән иде.* Г.Баруди

**Яхшыланып кую** Кинәт яхшылану

**ЯХШЫЛАП** *рәв.* 1) Тиешле дәрәҗәдә, кирәгенчә; рәтләп. *Бабасы күрсәткән җирне Әбүзәр бик яхшылап истә калдырган иде.* А.Тимергалин. *Ул татлытамактан умарталыкны яхшылап сакларга кирәк.* А.Гадел

2) Яхшы итеп, ныгытып, әйбәтләп; пөхтә итеп. *Миңнурый тәрәзә пәрдәсен яхшылап корды да ут кабызды.* Г.Әпсәләмов

3) Игътибарлап, дикъкать белән, җентекләп, бәйнә-бәйнә. *Мәхүп әби конверт эчен яхшылап карады.* А.Алиш. *Артларыннан килүчене дә яхшылап күздән кичерергә, аның ниятләрен чамаларга җай чыгачак.* А.Фәләх

4) Яхшы итеп, шәп итеп, шәпләп, күңелгә ярарлык. *Килдек, яхшылап концерт күрсәттек.* А.Хәмзин

5) Җайлап, уңайлап, иркенләп. *[Салих:] Я, менә яхшылап утыр.* Г.Исхакый

**ЯХШЫЛАТУ** *ф. сөйл. к.* **яхшырту**. *Кылт итеп: «Ник соң хәзер гәзитәне

*яхшылатмыйм?» – сөале хәтеренә килде.* Г.Исхакый. *Паспорттагы штамп нәрсәдер үзгәртә, яхшылата, дигән нәрсәгә ышанмыйм.* Шәһри Казан

**ЯХШЫЛЫК** *и.* 1) Яхшы кешегә хас сыйфатлар; кеше характерындагы уңай сыйфатлар; *киресе*: **усаллык**. *Ләкин гаепләрлек, шөбһә тотарлык урын юк: Җиһанша бабай – тирә-якта яхшылыгы белән танылган бер карт.* Г.Ибраһимов

2) Яхшы дип кабул ителү, уңай бәяләнү, әйбәт булу; сыйфатлы, затлы булу, шәплек. *Гармунга шәплеге, өстендәге киемнәренең яхшылыгы, үзенең үткенлеге аны авыл егетләре арасына кертә, аларның илтифатын җәлеп кыла иде.* Г.Ибраһимов

3) Файда, изгелек, кешегә эшләнгән яхшы гамәл. *Әллә үтә гамьсез иде инде ул чакта Галина, әллә апасына яхшылык итәм дип белепме, тотты да суга керде.* Г.Әпсәләмов. *Күпме яхшылык иткән, хезмәт күрсәткән инде ул безнең кечкенә авылга!* А.Гыйләҗев

4) Уңыш, шатлык, бәхет һ.б.ш. *Әгәр шулай икән, мөдир чыннан да Азатка яхшылык тели, бәлки әле, аны яклап та кала торгандыр.* А.Тимергалин

◊ **Яхшылык белән** 1) Берәр кешене куркыту, шүрләтү өчен кулланыла: яхшы чакта, ирекле рәвештә, үз теләгең белән. *[Сәрбиҗамал:] Зинһар, чык яхшылык белән, каравыл кычкырам.* Г.Камал. *Бер генә түгел, йөз әйтеп караган инде аңа – яхшылык белән дә, усалланып та.* В.Нуруллин; 2) Яхшылап, әйбәтләп, җае белән. *Гомер булса, бер яхшылык белән кайтарырмын, син, Бирем әкә, чамаңнан килсә, миңа менеп качарга бер ат бирсәң иде!* Г.Ибраһимов. **Яхшылыкка түгел (йөрми, сөйләми, кыланмый)** Берәр эшхәрәкәткә шикләнеп карап, канәгатьсезлек белдергәндә әйтелә. *Әгәр солдат, күңелен бикләп, эчтән янып-көеп йөри башласа, бу һич тә яхшылыкка түгел: я курка, я авырлыкны күтәрә алмый, я өеннән күңелсез хат алган.* С.Поварисов. *[Нәлимә:] Ул яхшылыкка йөрми.* Т.Миңнуллин. **Яхшылыгын кайтару** Яхшылыкка яхшылык эшләү

**ЯХШЫЛЫКЛЫ** *с. сир.* Яхшы ниятле, яхшы күңелле, яхшылык эшләүчән, кешелекле. *Рәхмәт инде, Вафа балалары гел шулай яхшылыклы булдылар.* Ф.Яхин

**ЯХШЫЛЫКТА** *рәв. к.* **яхшы чакта 2**. *[Батырҗан:] Мин сезгә әйтәм, яхшылыкта ташлагыз, юкса сөякләрегезне дә җыя алмассыз!..* Т.Гыйззәт

**ЯХШЫРТУ** *ф.* 1) Сыйфаты, эчтәлеге ягыннан югарырак, әйбәтрәк, өстенрәк итү, яхшы итү. *Табигать кешене, әгәр ул аны аңласа, яратса, яхшырта, чистарта, матурландыра.* Г.Әпсәләмов. *Балык ризыклары сөякләрне ныгыта, йокыны яхшырта.* А.Нәҗми

2) Тагын да яхшырак, уңайлырак итеп эшләү. *Җир йөзенә яңадан-яңа буыннар килә, һәрберсе үзенчә йортлар сала, һәрберсе шәһәрне үзенчә яхшырта, үзенчә бизи.* М.Маликова. *Аның бөтен сәләте һәм гомере шәһәр халкының тормыш-көнкүреш, хезмәт шартларын яхшыртуга багышланган.* В.Имамов

3) Югарырак, яхшырак күрсәткечләргә ирешү өчен, эш ысулларын камилләштерү. *Әмма бу тарафтан программа да, дәреслекләр дә шактый яңартылды һәм яхшыртылды, дип әйтергә була.* А.Әхмәдуллин

**Яхшырта бару** Торган саен яхшырту. *Завод көннән-көн ныгый, елдан-ел эшен яхшырта бара.* Ш.Камал

**Яхшырта килү** Электән, күптәннән яхшырту. *Иң зирәк табигать булып табигать тә үсемлекләрне, җан ияләрен әнә күпме дәверләр буена берөзлексез яхшырта килгән һәм шуның аркасында гына иң җитди, югары нәтиҗәләргә ирешкән.* Ф.Хатипов

**Яхшыртып җибәрү** Бераз яхшырту; яхшыртырга тотыну. *Тагы шуны да онытырга ярамый: шул көннәрдә төрле сәяси вакыйгалар безнең хәлне тиздән яхшыртып җибәрде.* Г.Исхакый. *Аларны сатып, егерме мең алтын акча китерделәр, һәркем бурычларын түләде, тормышларын яхшыртып җибәрде.* Ф.Яхин

**ЯХШЫРУ** *ф.* 1) Сыйфаты, эчтәлеге ягыннан өстенрәк, югарырак, яхшырак була бару, яхшыга әйләнү. *Аныңча, ир балалар кызлар белән утырса, тәртипләре яхшыра, тырышыбрак укыйлар.* З.Мурсиев // Яхшырак, уңайлырак, җайлырак булу. *Тормыш тагын да яхшыра.* М.Яһудин. *Түнтәр авыл халкының торак-көнкүреш хәле елдан-ел яхшыра.* Р.Зарипов

2) Сәламәтләнү, рәтләнү, әйбәтләнү, тазару, сихәтләнү. *Шулай итеп, тамагыбыз тую өстенә, Азатның демонстрациядән соң чак кына кырыла төшкән кәефе күзгә күренеп яхшырды.* А.Тимергалин. *Әнисенең дә бераз хәле яхшырды, ләкин ул барудан барыбер баш тартты.* А.Нәҗми

3) Эш, хезмәт, тикшеренү һ.б.ш. алымнары камилләшү. *Китапларның сыйфаты яхшыра.* М.Глухов

**Яхшыра башлау** Яхшырырга тотыну. *Малайның хәле күзгә күренеп яхшыра башлады.* Г.Әпсәләмов. *Сәер булса да, шушы эшләр яхшы нәтиҗә бирде – авыруларның хәлләре яхшыра башлады.* В.Исламетдин

**Яхшыра төшү** Бераз яхшыру; тагын да яхшыру. *Зиннуровның хәле беренче көннәрдәгегә караганда беркадәр яхшыра төшкән иде.* Г.Әпсәләмов

**Яхшырып китү** Соңгы вакытта яхшыру. *Минә хәлем яхшырып киткәндәй булды әле.* Г.Гыйльманов

**ЯХШЫСЫНУ** *ф.* Яхшы дип табу, мөмкин дип уйлау (гадәттә, юклык формасында: уңайсыз санау, оялу, уңайсызлану). *Мәдинә ханым авырыбрак торса да, Әбүзәр абзый, үзе киләм дигән кешегә килмә дип әйтергә яхшысынмады, рәхим итегез, диде.* Г.Әпсәләмов. *Мирвәлинең адашы яныннан тизрәк китәсе килде, яхшысынмады.* А.Гыйләҗев

**ЯҺҮД** *и. к.* **яһүди**. *Ул көнне гитлерчылар, маташа торгач, биш мең яһүдтән нибары йөз илле кешене генә «эвакуацияли» алдылар.* Г.Әпсәләмов

**ЯҺҮДИ** *и. гар.* 1) *к.* **еврей**. *Берничә эшче күтәрелде, аларны алу белән, баягы яһүди адвокат, аның артыннан Коля күтәрелде.* Г.Ибраһимов. *Яһүди кай якка карап та юл тотарга белмәде.* Ф.Яхин

2) Яһүдилек (*2 мәгъ.*) тарафдары

**ЯҺҮДИЛЕК** *и.* 1) Яһүди булу, еврейлык. *Яһүдилеген яшерү*

2) Муса пәйгәмбәргә иңдерелгән Тәүрат китабы тәгълиматы нигезендәге иң борынгы диннәрнең берсе; яһүдиләрнең дине. *Коръән дә Библия һәм Инҗил туган мохиттә барлыкка килгән, һәм аның яһүдилек һәм христианлык белән генетик элемтәләре – бердәм мәдәни дөньяның чагылышы гына.* А.Тимергалин

**ЯҺҮДИ́ЧӘ** *рәв.* **1.** 1) Яһүди телендә. *Аңа яһүдичә Рафаил дип кушсалар да, халык, җайлап кына, Рафаэльгә үзгәртә.* Шәһри Чаллы

2) Яһүдиләр кебек, шулар гадәтенчә. *Бәйрәмнәрне яһүдичә уздыру*

**2.** *с. мәгъ.* Яһүди телендә булган. *Яһүдичә китап сатып алу*

**3.** *и. мәгъ.* Яһүди теле. *Яһүдичә өйрәнү*

**ЯЧЕЙКА** *и. рус* 1) Зур берләшмә составына керә торган кечкенә оешкан төркем, берәмлек

2) *иск.* СССРда 1934 елга кадәр партия яки комсомол оешмасының беренчел иң кечкенә структур берәмлеге. *Аның эшен механический цехтагы комсомол ячейкасы бюросында да карап, комсомолдан чыгарырга булдылар.* А.Алиш. *Безнең ячейка рәисе – әкәмәт уңган кеше.* А.Гыйләҗев

**ЯШӘЕШ** *и.* 1) *филос.* Реаль чынбарлык. *Яшәеш кануннарын инкяр итеп, күбрәк илаһи, сихри кануннар буенча яшәргә мәҗбүр иде ул.* Г.Гыйльманов // Җәмгыятьнең материаль тормыш шартлары, яшәү шартлары җыелмасы

2) Яшәү, тормыш итү, көн күрү хәле, эш-хәлләрнең торышы. *Моннан соң безнең бар омтылыш, безнең уку, тырышлык, яшәеш алар исеме белән бәйләнәчәк...* А.Гыйләҗев. *Ә минә яшәеш көнендә аның өчен бердәнбер матурлык шушы сихри урман кызы булган.* Г.Гыйльманов

**ЯШӘР** *с. к.* **яшьлек** II. *Йөз яшәр наратлар шулкадәр юан: колач та җитми.* А.Тимергалин. *Мең яшә, мең яшәр Казаным!* Р.Сәлах

**ЯШӘРЛЕК** *с.* 1) *диал. к.* **яшьтәге**. *Шул көзне сабый Миңсылу белән ике яшәрлек Куйбагарны әйттерделәр.* Г.Ибраһимов

2) Яши алырлык, яшәрдәй. *Шәһәр думасында тузган йортларны бетерү программасы проекты кабул ителүгә, таза наратлардан салынган мең яшәрлек йортлар йокының иң тәмле вакытында дөрт итеп кабына да иртәнге якка кадәр янып юкка чыга башлады.* З.Мәхмүди

**ЯШӘРТҮ** I *ф.* 1) Яшь итү, яшь кешегә әйләндерү. *Яраткан хезмәте кешене яшәртә!* А.Гыйләҗев. *Су тынычландыра, яшәртә, көч, дәрт бирә.* А.Нәҗми

2) Яшь дип санау, яшь итеп күрсәтү, яшьсетү. *Бу кием аны яшәртә*

**Яшәртеп җибәрү** Кинәт яшәртү. *Кызыл төлке аның маңгае өстенә төшкән сары чәченә бик килешеп тора, ак йөзен яшәртеп җибәрә.* М.Маликова. *Әбекәйнең иреннәрендәге елмаюы, очкынлы карашы гүя аны яшәртеп җибәргән иде.* А.Мансуров

**Яшәртеп тору** Гел яшәртү; хәзерге вакытта яшәртү. *Яшь хатыны да яшәртеп тора...* Акчарлак

**ЯШӘРТҮ** II *ф. к.* **яшелләндерү**. *Яшәртәсем, су сибәсем килә Яшьлегемдә өзгән гөлемә.* В.Галиев. *Әле дә Ходай урманнарны ел да яшәртеп, үстереп тора.* Г.Хөсәенов

**ЯШӘРҮ** I *ф.* 1) Яшьрәк булып китү, яңару. *Ил яшәрә, безнең иске авыл да Танымаслык булып яңарды.* Г.Афзал. *Авыл үсә, яшәрә, матурая.* Г.Шәйхи

2) Яшьләр төсе керү, үзеңне яшь сизү. *Ул яшәргән иде*

**Яшәрә бару** Торган саен яшәрү. *Һәр җырлаган саен яшәрә бара бит җыр.* М.Хуҗин. *Ул яшәгән саен яшәрә бара, ахрысы.* З.Мурсиев

**Яшәреп китү** Кинәт кенә яшәрү

**ЯШӘРҮ** II *ф.* 1) Яшел төскә керү, яшелләнү; яшелләнеп күренү. *Җир яшәрә, агачлар яфрак яра.* Г.Әпсәләмов

2) Болытлар куерып, яшькелт-күгелҗем төскә кереп, яңгыр яварга тору турында. *Күк йөзе яшәрде*

**Яшәрә бару** Торган саен яшәрү. *Үсә Казан, һаман яшәрә ул, Бакчалары гөлгә төрелә. Бер-бер артлы калыккан ак йортлары Каурый болытларга үрелә.* Р.Вәлиева

**Яшәрә башлау** Яшәрергә тотыну. *Үләннәр яшәрә башлагач, Әүҗән яклaрына, туп ясый торган завудлар ягына чыгып киткән, ди.* З.Зәйнуллин. *Яшәрә башлаган болыт кап-кара булып бөтен күк йөзен каплап алды.* М.Гали

**ЯШӘРҮ** III *ф. сөйл.* Яшьләнү, яшь тулу. *Мин өйдә чакта шул хакта бер сүз чыгарга ярамый, хәзер күзләре яшәрә, йөзенә кара болыт заһир була да, тавышы үзгәреп, бугазына күз яше килеп тыгыладыр иде.* Г.Ибраһимов

**ЯШӘТҮ** *ф.* 1) *йөкл. юн. к.* **яшәү**

2) Берәр нәрсәнең эшен, хәрәкәтен дәвам иттерү, дәвам итү, бетмәү, юкка чыкмау. *Совет чоры өчен хас уңай нәфасәти принциплар белән бергә шушы өлкәдә зур кимчелекләр, асылда, тискәре юнәлешләр дә яшәде.* К.Гыйззәтов

**ЯШӘ́Ү** *ф.* 1) Гомер итү, тору. *Кешеләр белән дә янәшә бик тату һәм тыныч яшиләр.* А.Хәсәнов. *Авыр яшәделәр алар.* Г.Галиева

2) Күпмедер вакыт гомер итү, тереклек итү. *Минә шушы дәүләт бик озак – берничә йөз ел яшәгән.* И.Хуҗин

3) Нәрсә белән дә булса кызыксыну, нәрсәне дә булса тормышта иң әһәмиятле дип исәпләү. *Ул музыка белән яши*

4) Нинди дә булса тормыш алып бару. *Кеше ялгыз туа, ялгыз яши һәм бөрүзе үлә.* А.Нәҗми

5) Материаль як турында: ничек тә булса көн күрү, көн үткәрү, туклану. *Әтисе вафат, әнисе кече кызы белән үзе пенсиягә яши.* И.Нуруллин

6) Кайда да булса даими рәвештә тору, урнашкан булу. *Без күп милләтле илдә яшибез.* А.Хәсәнов. *Ул берничә ел чит илдә яшәде*

7) Берәр җирдә булу, очрау, бар булу. *Кем белә, бәлки, шул тирәдә аюлар да яшәгәндер...* С.Зыялы

8) Кем белән яки кемнәр белән билгеле мөнәсәбәттә, караштa булу. *Ике дус хәзер тату яшиләр, бер-берсенә кунакка йөрешәләр, ди.* А.Имамиева. *Бер ел буе гел тавышланып яшәдек.* Хезмәт даны

9) Кемгә дә булса өйләнеп яки кияүгә чыгып, гаилә булып тору. *Сугыштан соң Хафиз абзыйга тормышка чыгып яшәде.* Р.Зарипов

10) Законда, гамәлдә булу. *Дөньяда Рим җәлладларыннан да мәкерле җәзалаучыларны табуы кыен, чөнки гасырлар буена баш бирмәгән халыкларны һәм колларны җәзалап яшәгән римлылар адәм баласын җәзалауның мең төрле ысулын беләләр иде.* М.Хәбибуллин. *Редакциядә язылмаган канун яши.* Г.Гомәр

11) Актив, эшчән тормыш алып бару. *Авыру кешеләрнең кайберләре, алда ышаныч-өметләре булмаса да, яшьегәрле чакларында эшләгән эшләрен, кешеләргә кылган яхшылыкларын хәтерләп, шулар белән рухланып яши.* В.Нуруллин

12) *күч.* Саклану, онытылмау. *Кичәге көн хәтерләрдә яши.* Ф.Яхин. *Тик аларның һәркайсының йөрәк түрендә беренче мәхәббәте яшәде.* З.Кадыйрова

13) **яшә**, **яшәсен** *боер. ф. форм.* «Бетмәсен, дәвам итсен, чәчәк атсын» һ.б.ш. мәгънәдәге теләк яки шигырь. *Яшәсен совет табибы Гаделкәрим Абдуллович Чалдаев!* Г.Әпсәләмов. *Яшәсен туган илем, туган җирем, туган телем*! А.Нәҗми

**Яшәп калу** Яшәргә өлгерү. *Аның каравы без дә кешечә яшәп калырбыз, ичмасам.* Аманулла. *Әмир тырышатырыша ачып йөргән мәктәп нибары бер генә ел яшәп калды.* В.Имамов

**Яшәп китү** Билгеле вакыттан башлап яшәү. *Чыннан да, май урталарында бергә-бергә тату гына яшәп киттеләр.* В.Имамов. *Икенче көнне Синнәтулла картны чакырып никах укыттылар да бергә яшәп киттеләр.* А.Хәйретдинова

**Яшәп тору** Вакытлыча яшәү. *Хәзергә минем җәйге сарайда яшәп торырлар, беренче гаилә буларак, аларга*

*җир-су бирербез, бергәләп, йорт та салырбыз.* А.Гадел. *Хәлимнең югалуына ышанып бетә алмаганга гына яшәп тора.* Г.Гыйльманов

**Яшәп яту** *сөйл.* Хәзер, әле яшәү. *Өй эчендә барысы гөрләшеп яшәп яталар иде.* А.Әхмәтгалиева. *Мин дә шунда яшәп ятам.* А.Хәсәнов

**Яши башлау** Яшәргә тотыну. *Ире өчен куркып яши башлады Шәмсегаян.* А.Гыйләҗев. *Фатиха ялгыз яши башлады.* А.Нәҗми

**Яши бирү** Бернигә дә карамый яшәү. *Чатанның тамагы тук, өсте бөтен дигәндәй, үз язмышына буйсынып, бер көйгә яши бирә.* А.Хәсәнов. *Үгез үлсә – ит, арба ватылса – утын, дигәндәй, бернәрсәгә пошынмый, кайгырмый, үзе өчен барысын да әнисе хәл итәчәгенә җаны-тәне белән инанып, үз көенә яши бирә.* А.Әхмәтгалиева

**ЯШӘҮЧӘН** *с.* Яшәүгә сәләтле, озак яши торган. *Бу ике батыр, яшәүчән халык узган юллар – икесе дә безнең тарих: горурланырга кирәк.* Р.Батулла. *Безнең планетада атмосфера бик пычранды, шуңа күрә озак яшәүчән яңа вируслар барлыкка килде.* З.Мәхмүди

**ЯШЕ́-КАРТЫ** *җый. и. тарт. форм.* Яшьләр һәм картлар, яшьләр дә, картлар да. *Посёлок клубы гөр килә, яшекарты шунда җыелган.* С.Сабиров. *Кичү тирәсендә халык чуар: ир-ат, хатын-кыз, бала-чага, яше-карты, татары-урысы...* Р.Кәрами

**ЯШЕЛ** *с.* **1.** 1) Спектрдагы төп төсләрнең берсендә – зәңгәр белән сары арасындагы төстә булган; үлән, үсемлек, яфрак төсендәге. *Ул җиләрдән яшел калай түбәле йорт сакланып калган.* А.Алиш. *Яшел тышлы калын дәфтәр кинәт кенә иң якын сердәшемә әйләнде дә куйды.* А.Әхмәтгалиева

2) Үлән, агач һ.б. үскән, яшеллек каплаган, гомумән үсемлек дөньясы бай булган. *Күз ачып күз йомылмады, арба яшел урман эченә чумды.* Г.Исхакый. *Ә Һәдиябану исә, Гарифҗаны белән җитәкләшеп, ап-ак чәчәкле яшел болын буйлап атлады да атлады.* Г.Әдһәмова

3) Үләннән, яфрактан торган. *Берничә бөртек чәче тырпаен торган такыр башны хәтерләткән әлеге участокны җәй урталарында яңадан сөреп, яшел азык өчен үлән чәчә идек.* Д.Сирай. *Яшел ашлама туфракта файдалы микроорганизмнарны 1,5–2 тапкыр арттыра, ә бу – туфракның биологик активлыгын яхшырта.* Кызыл таң

4) Кузгалак, кычыткан һ.б.ш. ише ашарга яраклы үләннәрнең яфрагыннан әзерләнгән. *Күп халыкларда кычытканның яшь ботакларын азыкка кулланалар, алардан яшел щи бик тәмле була.* Мәйдан

5) Ашарга кыягы кулланыла торган (суган тур.). *Кыяр, помидор телемнәре, яшел суган, укроп белән бизәлгән мондый бишбармакка Сания апаның кияве Рәсим үлә дә китә инде.* А.Әхмәтгалиева

6) Ферментлаштыру үтмәгән, шул көе генә киптерелгән (чәй тур.). *Шул хәлдән соң, күршесе киңәшен тотып, яшел һәм бөртекле чәйләр генә куллана башлады.* А.Хәйретдинова

7) Яңа чабылган, яңа өзелгән; кибеп саргаймаган, киптерелмәгән, эшкәртелмәгән. *Күптән түгел генә Мәмдәлнең бер агае күлнең сусыл ярларыннан күп итеп яшел печән чаба.* А.Хәсәнов. *Көлтә итеп кысылган чи яшел печән атлаган саен авырая, бау җилкәне кисеп керә башлый.* Н.Көбәш

8) Өлгермәгән, җитлекмәгән (җиләк-җимеш, ашлык һ.б.ш. тур.). *Болай булгач дөнья матур, дуслар, яшел җиләк пешә карында.* Э.Мостафин

9) *күч.* Бик яшь һәм тәҗрибәсез. *Бераз яшьрәк һәм яшелрәк булса да, Сөләймановның уйлавынча, икеләнмичә алып барырга ярый торган малай иде ул.* И.Гази. *Яңа гына рабфак бетергән, моңарчы әле бер җирдә дә эшләмәгән яшел егет булуымны белгәч, [мехкомбинатта] бераз уйга калдылар.* Ә.Еники

10) *күч.* Колакка ятышсыз, кискен ачы, нормаль булмаган чәрелдек (тавыш тур.). *Әллә нинди яшел тавыш берлә --- бер кеше Коръән укырга тотынды.* Г.Исхакый. *Икенчесе исә берөзлексез тамак төбе белән яшел тавыш чыгарып үкерә дә үкерә.* Х.Камалов

**2.** *и. мәгъ.* 1) Чирәм, яшь үлән төсе. *Өй яшелгә буялган!* Г.Гыйльманов

2) *к.* **яшеллек** (*2 мәгъ.*). *Әллә кай арада яз җитте, клиника каршындагы бакчада өрәңгеләр, каеннар яшелгә төренде.* М.Маликова. *Яшеле уңган*

3) **яшелләр** *купл. тар.* Бер елга солдаттан калган рекрутлар. *Яшелләр каралып бер ун минут кына үткән иде, кызыл өйнең койма як ишегендә бер адәм күренде.* Г.Ибраһимов

4) Кеше һәм табигать арасында гармонияне пропагандалаучы, әйләнә-тирәне саклау принципларын яклаучы хәрәкәт тарафдары. *90 нчы еллар башында, демократия дулкынына бирелеп, яшелләр хәрәкәтенең таләп итүе буенча, без күп кенә производстволарны япкан идек.* Я.Шәфыйков. *Бер галимнәр, моның булуы мөмкин түгел, дисә, икенчеләр, бигрәк тә яшелләр, халыкны куркыныч урыннан кичекмәстән күчерергә, таш актаруны туктатырга, дигән фикер әйтте.* Ә.Әминев

**3.** *рәв. мәгъ.* Өлгермәгән килеш. *Арыш яшелрәк урылганга төшми, көлтәдә кала.* М. Гали

**ЯШЕЛБАШ** *и. зоол.* Үрдәк кошлар семьялыгыннан ата җенесенең башы һәм муены яшел булган кыр үрдәгенең бер төре; *русчасы:* **кряква**

**ЯШЕ́Л ЗӘҢГӘР** *и.* 1) Яшел белән зәңгәр төсләр арасындагы төс; *русчасы:* **цвет морской волны**. *Тукымасы сыек яшел зәңгәр иде.* Ф.Яхин

2) *фарм.* Медицинада тәндәге үлекләү, чабыру кебек авыруларны дезинфекцияләү, зарарсызландыру чарасы буларак файдаланыла торган сыеклык; *русчасы:* **бриллиантовая зелень, зелёнка**

3) Бакыр купоросы; *русчасы:* **медный купорос**

**ЯШЕЛЛӘНДЕРҮ** *ф.* Агач, куак, чәчәк һ.б. үсемлекләр утырту, чәчү, үстерү. *Их, шул хәзинәләрне табасы иде дә күлне чистартасы, тирә-юнен яшелләндерәсе иде.* Ф.Зариф. *Посёлокта яшәүчеләр моннан 20–30 ел элек тауларны яшелләндерә башладылар.* Р.Зарипов

**Яшелләндерә башлау** Яшелләндерергә тотыну. *Узган ел мәдәният йорты янын яшелләндерә башладык.* Яңа тормыш

**Яшелләндереп тору** Даими, гел яшелләндерү

**ЯШЕЛЛӘНҮ** *ф.* 1) Яшел төскә керү, яшькелт төс алу. *Ишегалдына кайткач, үзенең төнге юлдашы – пеше чыбыкны күрде. Аның нәзек очы үлән суыннан яшелләнеп беткән иде.* А.Гыйләҗев. *Урыны-урыны белән яшелләнгән тоник су.* Р.Сәгъди

2) Яшел булып тору, яшел булып күренү. *Сул як уйсулыкта яшелләнеп үскән борчак басуы да артта калды.* Р.Баттал

3) Яфрак белән, үлән белән каплану, яшел төскә керү. *Бакча рәткә керде, яшелләнде, тик яшелчәләрнең өлгергәнен көтеп, җыеп аласы гына калды.* А.Алиш. *Чәчәктә гөлләр, яшелләнде бакчабыз.* Т. Әйди

4) *сөйл.* Күгәрү, тутыгу. *Төймәләр бик искергәннәр, яшелләнеп, күгәреп беткәннәр иде.* Г.Гобәй. *Тимгел-тимгел*

*булып, яшелләнеп тутыккан кыңгырау нечкә генә тавыш белән чыңлап җавап кайтарды.* А.Шамов

5) *күч.* Ачу, нәфрәт, көнләшү, хәлсезлек сәбәпле йөз агарып, аксыл соры төскә керү. *Иннокентийның йөзе бер агарды, бер яшелләнде.* З.Мәхмүди

**Яшелләнә башлау** Яшелләнергә тотыну. *Ә ул арада мөһаҗирләрне төягән поезд яшелләнә башлаган болыннар һәм урманнар аша әкрен генә көньякка үрмәләде.* М.Галәү

**Яшелләнеп бетү** Тәмам яшелләнү. *Йорт биек бетон нигездә утыра, башы шифер белән ябылган, анысы иске, яшелләнеп беткән.* Ә.Әминев

**Яшелләнеп килү** Соңгы арада азазлап яшелләнү. *Бөтен җирдә яшелләнеп килә торган табигать.* Т.Гыйззәт. *Самолётка утыргач, мин Сәгадәткә яшелләнеп килгән урман-кырларны, җәелгән язгы суларны, авылларны, юллардан йөгерешкән автомашиналарны, тракторларны күрсәтергә тырышып азапландым.* Ф.Садриев

**Яшелләнеп тору** Вакытлы гына яшелләнү; хәзерге вакытта яшелләнеп күренү. *Җәй буе яшелләнеп торган агач шиңгән иде.* З.Сәгыйдә

**ЯШЕЛЛӘТӘ** *рәв.* Яшел килеш, яшел чагында. *Янәшә түтәл, яшел суган, Яшелләтә ничек өзәсе.* Җыр

**ЯШЕЛЛЕ** *с.* 1) Яшел төс катнашкан; яшел төсмерле. *Ул яшелле күлмәк кигән иде*

2) Яшел белән башка нindидер төсләр аралашкан, яшел кушылган катлаулы төстәге. *Айлар үткәч, Ташкент вокзалында, тулы йөзле, кара сакаллы, чалмалы, яшелле-сарылы чапан кигән бер адәмгә дүрт пот ак онга сатып җибәрделәр.* Г.Ибраһимов. *Бауман урамы яшелле-кызыллы реклама утлары белән буеннан-буена балкып тора.* Г.Әпсәләмов. *Кара җиләннәрен салып ташлап, яшелле-зәңгәрле чәчәкләр төшкән озын күлмәк киеп йөри башладылар, шундый ук чәчәкле яулык бәйлиләр.* Г.Гыйльманов

◊ **Яшелле-зәңгәрле** Ачы, ямьсез, нормаль булмаган чәрелдек һәм зәһәр (тавыш турында). *Кинәт, хатын, яшелле-зәңгәрле тавышлар чыгарып бер чинады да, тилебәрән орлыгы ашаган су анасы кебек, Мәннанга ташланды.* Аманулла. **Яшелле-мөшелле** *к.* **яшелле-зәңгәрле**. *Тегe яктан Таңсылуның яшелле-мөшелле тавышы ишетелә.* А.Гыйләҗев. **Яшелле-күкле** *к.* **яшелле-зәңгәрле**. *Мескен мәче бакаларны шалтыратып, яшелле-күкле тавышлар чыгарып, тузан туздырып чабып китте һәм, чатка борылып, күздән югалды.* А.Гыймадиев

**ЯШЕЛЛЕК** *и.* 1) Яшел булу. *Яшеллеге якты күзләремнең Сүнгән хәзер, карашым да сынган.* Ф.Яхин

2) Үсеп утыра торган үсемлекләр: яфрак, агач, куак, чирәм һ.б.ш. *Бөтен җирдә сагынып көтелгән яңарыш, саф яшеллек, кырларда, болыннарда чәчәкләр, игеннәр шаулап үсә.* Г.Әпсәләмов. *Култыкның ике як ярында да – яшеллек диңгезенә төренгән, хәйран калырлык шәһәр.* В.Имамов

3) Яшел үсемлек белән капланган урын. *Кая карама яшеллек, биек үләннәр, хуш исле чәчкәләр.* А.Хәлим

**ЯШЕЛЛИ** *рәв. к.* **яшелләтә**. *Уракны яшелли урган Мария бала кочаклап ялгызы калган.* Б.Камалов. *Кем әйтмешли, беркайчан да яшелли урмас.* М.Вәлиев

**ЯШЕЛЧӘ** *и.* 1) Азыкка дип бакчада утыртып үстерелә торган культуралар. *Безнең, агроном кебек, үзе яшелчәләр утыртып, яшелчә үстергән Галябыз бар.* А.Алиш. *Хәлил Карпычның яшелчә бакчасы һәм җимеш агачлары бакчасы барлыгын белә, ә өйләр – хуҗаның үз өе дә, ялчылар өе дә, төрле-төрле таллардан торган тал бакчасында урнашкан.* В.Ильясов

2) Шул культураларның чи килеш яки эшкәртеп ашала торган җимеше, тамыры һ.б. өлешләре. *Ике машинаның икесе дә агач, икмәк, яшелчә ташудан кайтып керми диярлек.* А.Гыйләҗев

**ЯШЕЛЧӘЛЕК** *и.* Яшелчә бакчасы. *Әмма суны, культуралы көтүлектә дә, яшелчәлектә дә, күп иттереп җиргә торбалар сузып салган көйгә сиптерәләр.* Э.Касыймов

**ЯШЕЛЧӘЧЕ** *и.* Яшелчәчелек белгече; яшелчәчелек белән шөгыльләнүче кеше. *Бригадирыбыз Артурның тартырга сигареты беткән икән, яшелчәче агай белән кибеткә дип киткән җирдән озак кына йөреп килде.* С.Сабиров. *Яшелчәче хатыннар, култык астына кыстырып, утау чүбе алып кайталар икән...* А.Гыйләҗев

**ЯШЕЛЧӘЧЕЛЕК** *и.* Авыл хуҗалыгының яшелчә культуралары үстерү тармагы. *1952 елда Ш.Сафиуллин кабат Нөнәгәргә кайта, яшелчәчелек бригадасына җитәкчелек итә, колхозның җимеш бакчасын булдыра.* Г.Мөхәммәтшин. *Тимер кулланган бу кабиләләрнең беренчесе – терлекчелек, икенчесе игенчелек, яшелчәчелек белән шөгыльләнгән.* Т.Әйди

**ЯШЕН** *и.* 1) Гадәттә ялт-йолт итеп үтә торган бормалы чаткылар рәвешендә атмосфера электрының һавада бушануыннан гыйбарәт табигать күренеше. *Тагын яшен чартлады.* А.Гыйләҗев. *Йокыга киттем генә дигәндә генә, аяктан егар җил бәреп егып, яшен яшьнәп, күк күкрәп чиләкләп яңгыр коя.* А.Нәҗми

2) *күч.* Шатлык яки нәфрәт кебек хисләр кичергәндә кинәт күзләрдә чагылып китә торган очкын, чаткы, нур турында. *Миңа таба аның күзләреннән яшен атылды.* Гали Рәхим. *Күлмәге яшел иде, Карашы яшен иде.* К.Булатова

◊ **Яшен суккандай** Көтелмәгәндә, кинәт булган нәрсәнең көчле тәэсир итүе турында. *Хәмдия яшен суккандай калтыранып китте.* Н.Фәттах. **Яшен тизлеге белән** Үтә тиз. *Заманында, бөтен төбәкне йомарлап тоткан Апанаев хәзинәсен тапканнар, дигән хәбәр яшен тизлеге белән таралып өлгерде.* А.Тимергалин. *Малай яшен тизлеге белән тышка атылып чыкты.* А.Хәлим. **Яшен тизлегендә** *к.* **яшен тизлеге белән**. *Пехота, әйтик, яшен тизлегендә киенеп ала да күз ачып йомган арада сафка килә дә баса.* С.Поварисов. *Тулай торакта яшен тизлегендә хәбәр таралды.* Н.Гыйматдинова. **Яшен утыдай (кебек, шикелле)** *к.* **яшен ташыдай**. *Очын очка ялгарга тырышып, әллә ничә эштә эшләп йөрүче сыңар канат әнисе, аз булса да файда китерим дип, дәресләрдән соң әле газета таратып, әле кибетләрдә промоутер булып үзенең дә акча эшләргә тырышуы, бүгенге чәчәкләрне дә, сөенә-сөенә, үз акчасына алуы яшен утыдай күз алдыннан сызылып үтте.* А.Әхмәтгалиева

**ЯШЕНЛӘҮ** *ф.* Бик якты булып, тирә-якны яктыртып, кабынып-кабынып алу; яшьнәү. *Яшен яшенли, күк күкрәп ала, һәм Җәллади күз алдында зур черек, кәкре ботаклы агачка әверелә.* А.Гадел. *Чыннан да, ялт-йолт яшенләп, көчле күк күкрәүләр белән килгән яңгыр ничек башлана?* С.Шәмси

**Яшенли башлау** Яшенләргә тотыну. *Хәзер килеп яшенли башлавы да бик ихтимал.* Р.Фәизов

**Яшенләп алу** Бераз яшенләү. *Күктә бераз яшенләп алды*

**Яшенләп тору** Хәзерге вакытта яшенләү. *Көн яшенләп тора*

**ЯШЕНЛЕ** *с.* Яшене булган, яшен белән үтә торган. *Берзаман шул карт яшенле көндә урманнан кайтып килә икән, ди.* Г.Ибраһимов. *Ап-аяз көнне яшенле яңгыр башланды.* Г.Гыйльманов. *Әнә ерактан, бик ерактан, дөбердәп, яшенле яңгыр килә.* З.Мәхмүди

**ЯШЕНЛЕ́-ДАВЫЛЛЫ** *с.* Яшенләп, давыллап үтә торган. *Көнбатыш ягыннан яшенле-давыллы көчле яңгыр килә иде.* Г.Бәширов

**ЯШЕ́Н ТАШЫ** *и.* Һавада юнәлешен төрлечә үзгәртеп хәрәкәт итә ала торган утлы шар формасындагы яшен. *Шул мизгелдә иртәнге күктән түбәнтен генә яшен ташы очып узды, аның якты эзеннән түгәрәк аланны кап урталай ярган куш салават күпере пәйда булды.* А.Тимергалин. *Яшен ташы сукса да, бу кадәр исебез китмәгән булыр иде.* А.Нәҗми

◊ **Яшен ташыдай (кебек, шикелле)** Җитез, җәһәт, тиз; сапкан ташыдай. *Яшен ташыдай җитез, чая кызны алыштырганнармыни!* Р.Батулла. *Һәм шулчак әллә нинди хатирәләр, яшен ташыдай, зиһенне яктыртып узды.* Ф.Латыйфи

**ЯШЕРЕК** *и. дини* Христианнарда, күз белән күреп, кул белән тотып карап булган гади әйберләр, гадәти гамәлләр аркылы Ходайның бәрәкәте иңә, дип күзаллауга нигезләнгән, Иисусның үзе тарафыннан билгеләнгән, дип саналган гыйбадәт; *русчасы:* **таинство**. *Керәшеннәрдәге яшерекләр дә могҗиза исәбенә керәләр.* А.Тимергалин. *Теләк итү – христиан кешесе өчен бик зур яшерек.* Алга

**ЯШЕРЕН** *с.* **1.** 1) Кемнән дә булса яшерелә торган, кемгә дә булса әйтелми, белдерелми торган. *Фәндәриснең шулай берни дәшмичә, яшерен план корып йөрүе моңарчы юньлегә китермәде.* И.Хәйруллин // Күпләргә билгеле булмаган. *Син аны нинди яшерен максат белән көтә идең?* А.Гыйләҗев

2) Легаль булмаган, законсыз оештырыла торган, рөхсәтсез эшләнә торган. *Фарук абый сугышка киткәч, авылда хәбәр таралды: имеш, йөргән кызының өендә яшерен типография булдырып, Советка каршы листовкалар басып ятканнар.* А.Гыймадиев

3) Бик яшереп саклана торган. *Аңарда табылган яшерен китаплар ничек, кайдан, кем аркылы алынганын әйтергә куша...* Г.Ибраһимов. *[Солтангалиев] Гафу үтенәсе, төзәләсе урында ул, киресенчә, Казанга, Башкортстанга һәм Кырымга яңа яшерен хатлар җибәрә.* Р.Мөхәммәдиев

4) *тар.* Россиядә 1917 елга кадәр сәяси җинаятьчеләргә каршы эшчәнлек алып барган. *Исмәгыйль бәй Гаспралыны үтерер өчен, яшерен бүлек Казаннан бер кешене җибәрә.* Р.Батулла. *Бу урамнардан, көймәле арбада, яшерен полиция күзәтүенә алынган студент Ульяновны Кокушкино утарына озаталар.* Казан утлары

5) Сайлаучының фикерен башкаларга мәгълүм итмичә белдерү мөмкинлеге бирә торган сайлау ысулы. *Яшерен сайлауны да тавышка куярга кирәк.* К.Кәримов. *Яшерен сайлауның нәтиҗәләре белән җыелышны таныштырганда, түбәндәге хәл ачыкланды – монысы инде күңелсез хәбәр – җыелышта катнашкан профсоюз членнарыннан кемдер бирәү местком составына тәкъдим ителгән бер кандидатның фамилиясен сызган.* Т.Миңнуллин // Шул ысул белән башкарылган. *Демократия булгач, демократия булсын: әлеге мәсьәләне иҗат көчләренең гомуми җыелышы хәл кылырга тиеш һәм бары тик яшерен тавыш белән генә.* З.Хөсния

6) Астыртын булган, маскировкаланган. *Газдал белән Руфинә арасында яшерен элемтә барлыгын беләләр, Кәукәбелҗәннәт юкта аларны туйганчы чәйниләр иде.* Ф.Садриев

7) *күч.* Үзе генә кичергән, үтә шәхси; йөрәк түрендәге, күңелдә яшерелгән, эчке. *Әлегә кадәр аның әтиемне һаман яратуын белү миңа яшерен өмет, килер көнгә ышаныч, якты хыял бирә иде.* А.Әхмәтгалиева. *Әмма шул ук вакытта күңеленең кайсыдыр почмагында яшерен дошманлык, гаепләү хисе дә юк түгел иде.* М.Кәбиров

**2.** *рәв. мәгъ.* Беркемгә белгертмичә, сиздермичә; качып. *Ул вакытларда бу эш өчен төрмәгә ябалар иде. Шуңа күрә бик яшерен эшләде.* Х.Камалов. *Уллыкка, кызлыкка бала алуны яшерен эшләмиләр.* Ф.Яруллин

**ЯШЕРЕ́Н-БАТЫРЫН** *рәв.* Яшереп, астыртын, сиздермичә. *Яшерен-батырын эш итәрлек ара да, чама да юк иде хәзер.* В.Нуруллин

◊ **Яшерен-батырын түгел** Сер түгел, яшереп булмый. *Яшерен-батырын түгел, мин үзем хатыннан уңмадым, иптәшләр.* Г.Афзал. *Яшерен-батырын түгел, бил-аяклары сызлауга түзә алмыйча, үзенә үзе кул салыр чиккә җиткән чаклары булды Ханәфинең.* В.Нуруллин. *Яшерен-батырын түгел, Габдерахман әфәнде, кызларыңны күргәч аптырап калдым: кайсын сайларга да акылым җитми...* А.Гадел

**ЯШЕРЕ́Н-ПОШЫРЫН** *рәв. к.* **яшерен-батырын**. *Бикчәнтәй бер елмайды, бер янә җитди төс алды һәм, күзләрен бер читкә текәп, юмакай тавыш белән: – Синнән яшерен-пошырын берни дә юк, Шәриф, – диде.* Ә.Шәмин

**ЯШЕРЕНҮ** *ф.* 1) Кемнән дә булса качу, кемгә дә булса күренмәслек булып урнашу. *Куаклар арасыннан кыштырдаган тавыш ишетеп, Тимерҗан черек агач янына куйган арба артына яшеренә.* А.Гадел

2) Берәр нәрсә артына ышыклану, шуннан торып нидер эшләү. *Җилдән бура артына яшеренү*

3) *күч.* Кемнең дә булса яклавына таяну, аркалану. *Ул чакта әле Назимов, Гитлер сугышчылары шулкадәр мәкерле булырлар дип: хатын-кызлар артына яшеренеп атакага килерләр дип һич тә уйламый иде.* Г.Әпсәләмов

4) *күч.* Нәрсәне дә булса ширма итеп файдалану. *Гражданлык җаваплылыгы аның үзен дә зур таләпләр куеп яшәргә, үтемле темалар артына яшеренмәскә, бөртек авырлыгын тойган башак кебек, сүз кыйммәтен тоярга өйрәтә.* М.Вәлиев. *Руханиларның икейөзлелеген, дини сүзләр артына яшеренеп, халык белән уйнауларын, гади халыктагы наданлыкның ишаннар өчен бик кирәкле булуын әйтә, социаль катламнар арасындагы каршылыкларны ача.* Р.Рахман

**Яшеренә бару** Торган саен яшеренү. *Соңгы елда атна-ун көнгә бер килеп торган хатларыңда үз күңелеңә тирәнгәрәк яшеренә бара идең сыман.* М.Галиев

**Яшеренә башлау** Яшеренергә тотыну. *Кояш Днепрга каршы калкулыклар артына кереп яшеренә башлады.* М.Юныс

**Яшеренеп бетү** Тәмам яшеренү. *Ләкин бу белгәннәре хәтеренең төрле почмакларына качып, яшеренеп беткән булып чыкты.* Г.Гыйльманов

**Яшеренеп йөрү** Гел, һәрвакыт яшеренү; озак вакыт яшеренү. *Беркемгә күренмичә яшеренеп йөрибез, дип уйласалар да, аларның икәүләшеп төнге каравыл булып йөрүләре күпләргә билгеле иде.* Н.Фәттах. *Йөзләргә, дистәләргә бүленгән тагын әллә никадәрле*

*крестьян отрядлары урманнарда яшеренеп йөри.* В.Имамов

**Яшеренеп килү** Әлегәчә яшеренү

**Яшеренеп тору** Даими яшеренү; вакытлыча яшеренү; хәзерге вакытта яшеренү. *Еракта гына яшеренеп торган өйләр, дачаларның тәрәзәләре кызыл алтынга манылды, әле генә тынтыныш күренгән яшел урман, аның арасындагы яланнар ут берлән янарга тотынды.* Г.Исхакый. *Хәлем китеп, икенче катта Тукай скульптурасы артына качып яшеренеп тордым.* А.Гыйләҗев

**Яшеренеп утыру** *сөйл. к.* **яшеренеп тору**. *Юлның икенче ягында кайчандыр Михман хезмәт иткән ябык хәрбиләр шәһәре урман эчендә яшеренеп утыра.* З.Кадыйрова. *Хакимиятнең өлкәдән килгән кунакларны, кирәкле кешеләрне ял иттереп, мунча чабындырып, сыйлый торган урыны бар: елга буенда, агачлык уртасында яшеренеп утырган авыл өе.* Г.Мирһади

**Яшеренеп яту** *сөйл. к.* **яшеренеп тору**. *Кыш буе боз астында яшеренеп яткан Якты күл суы бүген зәңгәр һава төсен күрде.* А.Алиш. *Кешедә шундый сәләтләр яшеренеп ятар – беленсә, үзен дә, күпләрне дә хәтта хәйран итәр.* Г.Хөсәенов

**ЯШЕРТЕН** *рәв.* **1.** Сиздермичә, яшерен, астыртын рәвештә. *Алар баштарак бер-берсен яшертен генә күзәтеп утырдылар, ләкин уйларын ничек кенә тирәнгәрәк яшерергә тырышмасыннар, карашлары әледән-әле очрашып торды.* В.Имамов. *Икесе дә яшертен генә бер егетне – Рәүфне яраталар.* Г.Галиева

**2.** *с. мәгъ. к.* **яшерен 1.** *Кая карама – яшертен заводлар.* А.Гыйләҗев. *Ниһаять, үз көчеңне беркайчан да бетереп күрсәтмә, көтмәгәндә һөҗүм итәргә яшертен гаскәрең булсын.* З.Мурсиев

**ЯШЕРҮ** *ф.* 1) Берәр затны яки берәр предметны күренмәслек итү, качыру. *Сәлимә әлеге кәгазьләре белән бармак буе карандашын яңадан яшерде.* Г.Бәширов. *Барый, үзе дә сизмәстән, пакет тоткан кулын артка яшерде.* А.Гыймадиев

2) Сер итеп саклау, белгертмәү. *Яшермим: туган авылымны эзләп табу уе миңа соңрак килде.* А.Әхмәтгалиева

3) Сиздермәү, күрсәтмәү (хис, халәт тур.). *Ул инде үзенең мәхәббәтен яшерми, аңардан оялмый, курыкмый иде.* Г.Әпсәләмов. *Ана кеше баласын күкрәгенә кысты да нәфрәтен яшермичә иренә карады.* Р.Батулла

4) Берәр начар, тискәре тәэсирдән саклау, ышыклау. *Ә монда шатланып булмый: җир өстендә асфальт зонтик – җирне яңгырдан яшергәннәр.* Р.Харис. *Инспектор, йөзен чәнечкеле кайнар җилдән яшерә-яшерә, кабат ирennәрен ялап куйды.* Ш.Шәйдуллин

5) *куч.* Өртү, каплау, яшереп калдырырга ярдәм итү. *Аулак урам, куак артларына Нинди җинаятьне яшердең?* Р.Корбан. *Тамара өйдәшен юылмаган савыт-саба өчен үтерүен яшерми.* Әлмәт таңнары

**Яшерә бару** Булган берсен яшерү. *Менә шулай, гөнаһлысын да, гөнаһсызын да зират үзенә ала бара, булган серләрне яшерә бара.* З.Мурсиев

**Яшерә башлау** Яшерергә тотыну. *Гайшә ханым, конвертны алып, әүвәлге урынына – өстәл тартмасына яшерә башлагач, Шубин: – Бу хатны миңа бирмәссезме икән? – дип сорады.* З.Бигиев

**Яшереп йөрү** Берникадәр вакыт яшерү. *Яшереп йөргән була бит, кара син аны!* А.Гыйләҗев. *Сәвитне сүгеп, алтыннарын яшереп йөргән байлар өряңа кибетләр ачалар, туктап калган фабрикларны эшләтә башладылар.* Г.Галиева

**Яшереп тору** Даими, гел яшерү; вакытлыча яшерү; хәзерге вакытта яшерү. *Лена үзенең йөрәк тибешләрен яшереп тормаган – хатка теркәп барган, миңа озата торган.* А.Гыйләҗев

**Яшереп утыру** *сөйл. к.* **яшереп тору**. *Әтисе белән әнисенең үзара сөйләшкәнен сәерсенеп тыңлап утырган кызларыннан һаман да сер яшереп утыруның кирәге юк, диптер инде, Миңниса апа Саниягә дәште.* А.Фәләх

**ЯШМА** *и. гар.* **1.** Килеп чыгышы, составы һәм төсе белән төрле булган тау токымы; сәнгать әсәрләре, бизәнү әйберләре ясау һ.б.ш. өчен кулланыла торган ярымкыйммәтле таш. *Юлга чыгар алдыннан аның сул колагындагы алкасын салдырып алдылар, тамгалы яшма ташын – ышаныч билгесен – кире бирделәр.* Н.Фәттах

**2.** *с. мәгъ.* Шул таштан эшләнгән. *Затлык бүләк – яшма тартма Өстәлемдә балкый.* Х.Мөдәррисова

**ЯШМАК** *и.* 1) Мөселман хатыннарының күзләрен генә ачык калдырып, башын һәм йөзен каплый торган яулык. *Чигүле яшмак бөркәнү*

2) *к.* **нашмак**. *Кәләшкә яшмак кидерәләр*

**ЯШҮСМЕР** *и.* 12–16 яшьлек ир яки кыз бала; үсмер. *Кияү ишек бавын тартып җибәрде; эчтән кунак килен келәне ычкындырды; өйгә зур толыплы, кама читле бүрекле таза бер егет керде; аның белән бергә үк кияү егете, тагы берничә ир, берничә яшүсмер керделәр.* Г.Ибраһимов. *Шул тау итәгенә җитәрәк, Сәүбән аның башында утырган бер яшүсмер баланы күреп алды.* Г.Гыйльманов

**ЯШЬ** I *с.* **1.** 1) Әле генә туган. *Әле менә Саимә яшь бала белән утыргач, мал-туар карарга вакыты юк, дип кенә сыерны Хәдичә апага биреп тордык.* Г.Галиева // Балигъ булмаган, җитлекмәгән; бала яшендәге

2) Урта яки олы яшькә җитмәгән. *Мин яшь кеше, көчем җитәрлек – җәяү барырмын.* А.Гадел. *Аңардан гәүдәле яшь адәм төште дә идарә бинасына таба кызу атлап китте.* Ф.Яхин

3) Балаларны ата-анасыннан аерып күрсәткәндә фамилия алдыннан әйтелә. *Яшь Вахитов боларның барысын да күңеленә якын алып калган һәм, вакыты җиткәч, ул аларны искә төшереп, агитация коралы итеп файдалана белгән.* И.Низамов

4) Яңа гына, күптән түгел үсеп чыккан; җитлекмәгән (үсемлек тур.). *Урамга асфальт җәелгән, яшь агачлар утыртылган.* Г.Әпсәләмов

5) Яңа гына өлгергән яки өлгереп кенә килгән (яшелчә, җиләк-җимеш тур.) *Яшь кыяр*

6) Яңа оештырылган, яңа төзелгән. *Муса гомерен бер әнисенә багышлый алмады, бар күңел җылысын яшь иленә бирде.* Г.Әпсәләмов. *Тиздән яшь коллектив аерым өлешләрне әзерләүдән аяк кимен тулаем җитештерүгә күчә.* Т.Әйди

7) Нинди дә булса өлкәдә күптән түгел эш башлаган, тәҗрибәсез. *Йортта утын турап яткан җиреннән мәктәп мөдире кабинетына йөгереп кергән яшь укытучы каушап калды.* З.Мурсиев. *Шуңа да биредә төрки яшьләр оешмалары җитәкчеләре, яшь шагыйрь һәм язучылар катнаша.* Шәһри Казан

8) Яңа кияүгә чыккан яки яңа өйләнгән. *Утыз ел элек Мәхүп бу йортка яшь килен булып төшкән иде.* А.Алиш. *Мәүлиханың холкын яшь кияү үзгәртә алмады – Биктимер дагалый алырлык хатын түгел иде ул юртак: төнләтөнлә иске сукмакларына төште*

*Мәүлиха, печәнлектә, арба асларында яңадан-яңа кияүләрне куенына ала торды...* А.Гыйләҗев

**2.** *и. мәгъ.* 1) *сөйл.* Яңа гына өйләнешкән егет белән кыз. *Насыйп булсын ике яшькә рәхәт гомер итәргә.* Г.Камал. *Яңа кушылган ике яшь — бәхетле минутлар эчендә яши башладылар.* Г.Ибраһимов

2) **яшьләр** *күпл.* Яшь кешеләр, яшь буын. *Берничә ел элек, кыш көне, бер төркем яшьләр, кереп, кавырсын чәйнек тә калдырып киттеләр.* А.Хәйретдинова. *Яшьләр дискотекага җыелган.* А.Гадел

**3.** *хәб. функ.* Үзеннән яшь кешегә карата кисәтеп, тәртипкә чакырып, хуплап бетермичә һ.б. очракларда әйтелә. *Волкомга председатель сайлау мәсьәләсе килеп баскач, Миңнулла, һич икеләнмичә, ул урынга әнә шул Сабитов Фәйзулланы тәкъдим иткән иде. Әмма, булдыра алмас, яшьрәк әле ул, дип, аның фикерен хупламадылар.* В.Нуруллин. *Синең башың яшь әле, синең белән үскәчрәк сөйләшербез.* Ф.Яруллин

◊ **Яшь хатын** 1) *этн.* Полигамик гаиләдә берничә хатынның соңгысы, иң яше. *Бервакыт бабаң, көтеп-көтеп тә өмете киселгәч, миңа болай диде: «Зариф улым, сиңа, Зөлкамал киленнең рөхсәте белән, яшь хатын алып кайтырга кирәк».* Г.Галиева. *Кызы Ләмига тугач, миңа ир бала кирәк, дип, яшь хатын алып кайтты.* Д.Каюмова; 2) Хатыны үлгәч яки аерылгач алган икенче хатын. *[Сиражетдин:] Хатынны җибәрәм, яшь хатын алам, йорт салам, афтамабил алам!* Г.Камал. **Яшь әни** Үги ана. *Ашау-эчүнең дә рәте китте. Мин инде аркылыга үлчәдем, буйга уйладым да сезгә яшь әни алып кайтырга булдым...* Р.Ишморатова

**ЯШЬ** II *и.* 1) Кеше яки хайван гомеренең бер елы. *Рафаэльгә яшь ярым.* Г.Шәйхи

2) Туган көннән алып үткән вакыт, ел исәбе; кешенең, хайванның, үсемлекнең яшәү чоры, периоды. *Нәрсә инде кешегә ниндидер илле-туксан яшь гомер!* Ә.Мушинский. *Хәзер яшем олыгайды.* Г.Гыйльманов

3) Гомернең билгеле бер чоры. *Ул – элегрәк елларда байтак вакыт районның партия комитетында эшләгән җаваплы хезмәткәр – пенсия яше җиткәч, газетага күчкән иде.* З.Хөснияр. *Ләкин коммунистлар алдатмый, армия яше җитү белән, моңарчы комсомолдан читкә тибәрелеп килгән берән-сәрән егетләрне ашыгыч рәвештә яшьләрнең бу оешмасына тарталар, комсомол райкомы аларга тиз генә билет штамплап бирә.* Безнең гәҗит

◊ **Яше җиту** Балигъ булу, өлгерү. *Яше җиткәч, Бакый авыл малайлары белән бер-ике ел мәдрәсәгә йөрде.* Г.Әпсәләмов. **Яше үтү** Нәрсәне дә булса эшләү өчен олыгайган, вакыты узган булу. *Эш эшләрлек егет чагы – яше үткән.* Г.Сөнгати. *Кызның яше үтеп бара.* Р.Рахман. **Яше чыгу** *к.* **яше үтү**. *Мәрхәбәнең егет сайлаудан яше чыгып бара иде – Заһри кызның иң нечкә кылына чиртте.* М.Мәһдиев. *Комсомолдан яше чыгуга, дине исламга әйләнеп кайтты, активистка булуларын яшьлек юләрлегенә, шайтан сараштыруына санап, шул чорларына бәддога укып тәүбә итте.* Ф.Яхин

**ЯШЬ** III *и.* Елаганда, бик нык дулкынланганда яки көчле авыртудан күздән бүленеп чыга торган төссез, үтәкүренмәле тозлы сыеклык. *Ак кирәк дип, пакь кирәк дип, күпме күз яшь түкмәдем!..* Г.Тукай. *Сакаллы кешенең күзеннән борчак-борчак яшьләр акты, ул чынлап та елый иде.* А.Алиш

◊ **Яшькә тыгылу** Хисләрнең күплегеннән яки рухи газаптан артык дулкынлану, еларга тору. *Галимҗанны сабый чагындагыдай кысып-кысып сөеп, бит очларыннан чүт-чүт үбеп алгач, ананың күзләре яшькә тыгылды.* С.Поварисов. *Таһирның күзләре генә түгел, күңеле яшькә тыгылды.* Г.Гыйльманов. **Яшь төшү** Кемнең дә булса берәр кешене каргап елавы аркасында, ул кешегә начарлык, бәла, бәхетсезлек килү. *Кагылмагыз сыерыбызга, Ятимнәрнең яше төшәр.* Ф.Яруллин. *Рәнҗетмиләр яраланган кошны, Яше төшәр, тимә син аңа!* Э.Шәрифуллина

**ЯШЬ-ҖИЛБӘЗӘК** *җый и. к.* **яшь-җилкенчәк**. *Тимер хутлы арбаларга пар атлар җигеп, яшь-җилбәзәк урам урап йөри.* М.Юныс

**ЯШЬ-ҖИЛКЕНЧӘК** *җый. и.* Яшьләр, яшь кешеләр, егетләр-кызлар. *Авылның бу очында яшәүче бала-чага, яшь-җилкенчәк, гадәттәгечә, иске мәктәпнең спорт мәйданчыгына җыелды.* А.Гыймадиев. *Барча яшь-җилкенчәк, карт-коры, күл буенда куна-төнә ятып, ашлык урды, көлтә бәйләде.* В.Имамов

**ЯШЬКЕЛТ** *с. ким.* 1) Сыек яшел, ачык яшел. *Ракетаның яшькелт тоныкяктысында ак халатлы бик күп финнар күренде.* Г.Әпсәләмов. *Йорт янындагы бакчада алмагачлар арасына тартылган кер бавында очып китәргә җыенган дәү аккош кебек ак күлмәк җилферди, бакча як тәрәзә төбендә зәп-зәңгәр вазада яшькелт үги ана яфраклары балкып утыра иде.* А.Гыйләҗев

2) Берникадәр яшел төсмер кушылган катлаулы төсләрне билдергәндә кулланыла. *Вәзирәнең яшькелт-соры күзләреннән аның нәрсә уйлаганнарын аңлап ала торган түгел иде.* Р.Гаязетдин

**ЯШЬКЕЛТЕМ** *с. к.* **яшькелт** (*1 мәгъ.*). *Яр читенә үк терәп салынган тегермәннең бүрәнәләре, яңгырдан каралып, тимер төсенә кергән, такта түбәсе тимгел-тимгел күгәргән, урыны-урыны белән яшькелтем мүк белән капланган.* Р.Вәлиев. *Хәер, инде утырган кар әллә зәңгәрсу, әллә алсу, әллә яшькелтем, әллә күксел иде.* Ә.Гаффар

**ЯШЬЛӘВЕК** *и. диал.* Яшь үлән. *Ваһапов янында да Мостафаның үзен иркен тотуы, «браток»ның әледән-әле аның салпы ягына яшьләвек кыстыруы исенә төште.* Т.Галиуллин. *Арбасына яшьләвек чабып салган.* Мәйдан

**ЯШЬЛӘЙ** *рәв. диал. к.* **яшьли**. *Атасы яшьләй, авариягә эләгеп, вакытсыз вафат булды.* А.Гадел. *Гомер үтеп бара, теләккә яшьләй ирешергә кирәк булгандыр, мөгаен.* М.Хуҗин

**ЯШЬЛӘНҮ** *ф.* Күзгә яшь килү, яшь тыгылу. *Аның уйчан зәңгәр күзләре яшьләнде.* Г.Әпсәләмов. *Күзләр әле һаман да әче борычтан яшьләнәләр.* А.Нәҗми

**Яшьләнә башлау** Яшьләнергә тотыну. *Аның уң күзе авырудан соң нишләптер эренли, яшьләнә башлады, йокыдан торганда шул күз керфекләре ябышып ката, сулы ачылса да, уңы ачылмый иде.* Р.Батулла. *Язмый калды, чөнки аның тозлы тузан комыннан яшьләнә башлаган күз карашлары теге ике бөртек җемелдәвекне кабат эзләп таптылар.* Г.Гыйльманов

**Яшьләнеп бетү** Тәмам яшьләнү. *Күзләре яшьләнеп бетте, аякларына суык йөгерде.* М.Әмирханов

**Яшьләнеп тору** Гел, еш яшьләнү; хәзерге вакытта яшьләнү. *Аның уң күзе нигәдер еш яшьләнеп тора.* Н.Хәсәнов

**Яшьләнеп чыгу** Кинәт, көтмәгәндә яшьләнү. *Атасының күзләре яшьләнеп чыкты.* Р. Гаязетдин

**ЯШЬЛӘ́РЧӘ** *рәв.* 1) Яшьләргә хас булганча. *Яшьләрчә киенгән, кара күзлектән, «мыек» җиткергән бер егет сагыз чәйнәп биегән була.* А.Гадел.

*Каршысында, чигә чәчләрен каралтып, яшьләрчә юка гына мыек та җибәргән, заманча фырт киемдә Хәмит абыйсы басып тора иде.* Р.Рахман

2) Яшь вакыттагыча, зур дәрт белән. *Зәкәрия шушы хәбәрне көтеп кенә торган диярсең, яшьләрчә җәһәт кенә сикереп торып, гимнастёрка чабуларын тарткалый башлады, изү төймәләрен элəктерде, пилоткасын рәтләде.* Г.Гыйльманов. *Аның моңа әллә ни исе дә китмәде: «Кырык биш чакрым нәрсә ул! Автобус йөреп тора ла...» – дип, яшьләрчә бик җиңел фикер йөртте.* Г.Әдһәмова

**ЯШЬЛӘТӘ** *рәв.* Яшьли, яшьтән үк, яшь килеш. *Бигрәк яшьләтә күп авырлык күргәнгә, Ходай мине шулай озын гомер белән бүләкләгәндер инде.* Туган як

**ЯШЬЛЕ** I *с. к.* **яшьлек** II. *Мәдрәсәсендә кырык-илле яшьле хәлфәләр булса да, шәкертләр дә күп булса да – нә дөнья хәленнән вә нә башкасыннан хәбәре булмаган бичаралар иде.* З.Һади

**ЯШЬЛЕ** II *с.* 1) Яшь (III) тулган, яшьләнгән. *Малайның яшьле күзләрен күреп, карт, сукрана-сукрана, тагын уңга кереп китте.* А.Гыйләҗев

2) Күп газаплар китергән, авыр ел. *Яшьле елның авырлыгы төште аякка.* М.Җәлил

**ЯШЬЛЕК** I *и.* 1) Сабый чактан алып җитлеккәнгә кадәрге еллар; яшь чак. *Егет яшьлек, мәхәббәт, зәңгәр күзле кыз турында җыр җырлый иде.* А.Мансуров

2) Яшь булу хәле

**ЯШЬЛЕК** II *с.* Билгеле яшьтә булган, билгеле яшьлек. *Унбиш яшьлек Алмаз андый чакта, Радикка карап, чын мәгънәсендә көнләшә.* А.Хәйретдинова. *Ә мин аның янында тугыз-ун яшьлек малай гына.* В.Нуруллин

**ЯШЬЛЕ́-КАРТЛЫ** *с.* Һәм яше, һәм карты булган, берсе яшь, берсе карт булган. *Җитмәсә тагын, бер иргә – яшьле-картлы ике хатын.* Г.Ибраһимов

**ЯШЬЛИ** *рәв.* Яшь чагында, яшьтән үк, яшь килеш. *Яшьли ятим калып, үги ана кулында үскәнгәме, Маһибәдәрнең тавышы да, йөреш-торышы да үз әнкәсен хәтерләтә иде аңа.* А.Гыйләҗев. *Бик яшьли малаебыз югалды.* Г.Гыйльманов

**ЯШЬНӘ́Ү** *ф.* 1) *сөйл. к.* **яшенләү**. *Утлы кисәү эләккән эт яшен яшьнәгән саен дерт итәр, ди.* Мәкаль

2) *күч.* Тазалык, яшьлек, көр күңеллелек ташып тору, нәрсәгәдер дәртләнеп, ашкынып тору турында. *Яшьлегендә яшьнәмәгән картлыгында кала алса да танылмас.* Мәкаль

3) *күч.* Чагылу, сизелеп китү. *Кызның уйлары арасында бер шиклесе дә яшьнәп узды.* Г.Минский

**Яшьни башлау** Яшьнәргә тотыну. *Яшен яшьни башлый, күк күкрәгән авазлар, җилме, нәрсәдер улаган тавышлар ишетелеп ала.* К.Җәмит

**Яшьнәп тору** Еш, гел, даими яшьнәү; хәзерге вакытта яшьнәү. *Юкса әле күңелнең «Яшим!» диеп яшьнәп торырга тиешле чагы да бит...* Г.Бәйрәмова

**ЯШЬСЕНҮ** *ф.* Артык яшь дип карау, тәҗрибәсезгә санау. *Мәгәр күрде, сиздe: кала түрәсе сизелер-сизелмәс кенә елмая, аны яшьсенә, баласыта.* М.Хәбибуллин

**ЯШЬСЕТҮ** *ф.* Кемне дә булса бик яшь итеп санап, җитди кабул итмәү, исәпләшмәү, баласыту. *Күп гаиләләр нефть өлкәсендә эшлиләр, эшләре авыр булуга карамастан, балалары белән шөгыльләнергә вакыт табалар, мине, яшь егетне, бер дә яшьсетмичә, укытучы буларак кабул итәләр, без куйган таләпләрне берсүзсез үтиләр иде.* Ә.Исхаков

**ЯШЬТӘН** *рәв.* Яшь вакыттан, яшь чактан ук. *Мин яшьтән романтик идем, гомеремне дә романтик булып үткәрдем.* Г.Әпсәләмов. *Кыйммәтле даруларга акча кирәк булды, уку хакындагы татлы хыялларын онытып, Зәйтүн яшьтән авыр хезмәткәялланды.* Г.Гыйльманов

**ЯШЬТӘШ** *и.* **1.** Кем белән дә булса бер яшьтәге, бер елгы кеше. *Сагындыра яшьтәш, карендәшләр, Туган-үскән газиз ил генәм.* З.Бәшири. *Таймас та алтынчыны тәмамлап җиденчегә күчкән, ягъни Рәүфләр белән яшьтәш икән...* А.Тимергалин

**2.** *с. мәгъ.* 1) Бер яшьтәге, бер елгы. *Баласыз кешеләр балалы булган, сакалсызлар сакаллы булган, сакаллылары карт булган, яшьтәш егетләре өйләнгән, ата булган, яшьтәш кызлары кияүгә китеп беткән.* Г.Исхакый. *Амбар мөдире Галиулла абзый – Закирҗанның атасы белән яшьтәш кеше – кыш уртасында ашлыкны урыннан кузгатуга каршы килде.* З.Хөснияр

2) Берәрсе туган елда салынган, төзелгән, сатып алынган һ.б. нәрсәләр турында. *Әти билендәге капчыгын ипли, өч сажиннан ала торган, үзе белән яшьтәш чыбыркысын бөтен авыл буен яңгыратып бер шартлата да, малларга якын килеп, куе калын тавышы белән: «Һайт, малкайлар!» – дип, көтүгә кузгалырга әмер бирә.* Г.Ибраһимов

**ЯШЬТӘШЛЕК** *и.* Яшьтәш булу. *Якташлык шикелле, яшьтәшлек тә кешеләрне якынайта.* Ш.Галиев

**Я́ЩИК** *и. рус к.* **әрҗә**. *Кызлар аптеканың барлык медикаментларын ящикларга, капчыкларга тутырдылар.* Г.Әпсәләмов. *Карчык ящик янына килде.* М.Кәбиров

**Я́ЩИКЛЫ** *с.* 1) *к.* **әрҗәле**. *Шул чак ящиклы арбага җигелгән пар ат килеп җитеп, комбайн белән янәшә бара башлады.* Г.Гобәй

2) *сөйл.* Ящиктагы, ящикка салынган. *Хөсәен, анда безнең ящиклы төргәк бар иде арткы кабинада, керт әле шуны.* Ф.Хөсни

**Я́ЩУР** *и. рус вет. к.* **тилчә**. *Англиядә ящур икән, токарлык бары шуның аркасында гына, дип шәрехләде әлеге хәлне Галәветдин Минтаһирович.* З.Хөснияр. *Икенче елны ящур дигән авыру чыгып, ферма малын кырды.* Х.Камалов

**Я́ЩУРЛЫ** *с. к.* **тилчәле**. *Ящурлы сыер*

**Я-Я** *ы.* 1) Әңгәмәдәшенең сүзен дәвам итүен теләгәндә, сөйләвен, җавабын ашыктырганда кулланыла; хуш. – *Я-я, коткардымы соң инде синең Аллаң? – диде ул, мәкерле көлеп.* Ш.Алпар. *Я-я, шуннан, нәрсәгә ирешә соң бичәң?* Ф.Имамов

2) Көчлерәк өндәү, боеруны белдерү өчен кулланыла. – *Я-я, рәтләп сөйлә, рәтләп! – дип кычкырды Шаммасов трубкага.* Д.Гыйсметдинов. *Нәрсә кыланасың инде, хәерче бет! Я-я, ярар, бу теманы яптык.* Н.Гыйматдинова. *Я-я, әйтеп бетер. Нәрсә димәкче буласың?* А.Нәҗми

3) Ярый, ярар, яхшы. *Я-я, утыра бир, начармы-яхшымы, мин бу өйнең хуҗасы, шулаймы?!* М.Хәбибуллин

**ЭЧТӘЛЕК**

Сүз башы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3
Сүзлектән файдаланучылар өчен белешмә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 4
Шартлы кыскартылмалар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
Татар алфавиты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
Сүзлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13

Справочное издание

**ТОЛКОВЫЙ СЛОВАРЬ**
**ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА**
(на татарском языке)

**Том VI**
**(У – Я)**

Редакторы: *Н.К. Нотфуллина, А.А. Давлетова*
Корректоры: *Н.К. Нотфуллина, А.А. Давлетова*
Компьютерная вёрстка *Н.Т. Абдуллиной*

Подписано в печать 08.12.2021.
Формат 84×108 $^{1}/_{16}$. Бумага офсетная. Гарнитура Times New Roman.
Печать офсетная. Усл. печ. л. 95,8. Уч.-изд. л. 124,5.
Тираж 1000 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20